ТАТАР

ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

# ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

БАШ МӨХӘРРИР М.Х.СӘЛАХОВ

## 5
## Р–Та

КАЗАН
ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ ҺӘМ ТӨБӘКНЕ ӨЙРӘНҮ ИНСТИТУТЫ
2016

УДК 94(470.41):031
ББК 63.3(2Рос=Тат)2-64 я2
Т 23

ҖАВАПЛЫ МӨХӘРРИР
Г.С.САБИРҖАНОВ

Баш гыйльми мөхәрририят

М.Х.Сәлахов (рәис), И.А.Гыйләҗев (рәис урынбасары), Р.К.Абдуллин, А.Г.Әхмәдуллин, Н.М.Вәлиев, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, В.З.Гарифуллин, М.Г.Госманов, Р.Г.Госманов, М.З.Зәкиев, Г.Г.Җиһаншин, А.А.Җәләлов, Д.М.Исхаков, Е.П.Казаков, В.П.Кандилов, А.Н.Латышев, Х.Й.Миңнегулов, М.К.Михайлов, К.М.Салихов, М.М.Сәфәров, Н.А.Сәхибуллин, И.Р.Таһиров, Җ.И.Фәйзрахманов, Р.М.Харисов, Р.С.Хәкимов.

ISBN 978-5-902375-12-8

© ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2016.
РФнең «Авторлык хокукы һәм эргәдәш хокуклар турында» Законы нигезендә саклана.
Китап материалларын ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының язма рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

# Р

**РАБГУЗИ́** Насреддин бине Борһанеддин (13 йөзнең 2 нче яртысы — 14 йөзнең 1 нче яртысы), язучы. Төрки телдә язган. Чыгышы б-н Алтын Урданың көнчыгыш төбәгеннән. Харәземнең Рабат Угыз авылында казый. Тәхәллүсе шул урын исеме б-н бәйле. Аннан соң Насыйр әд-дин Тукбуг әмирнең яраннары арасына эләгеп, Мавәраәннәһернең үзәгенә күчеп китә. Урта гасырлар төрки язма әдәбияты ядкәрләреннән «*Кыйссас әл-әнбия*» («Пәйгамбәрләр турында кыйссалар», 1310–11) дини әсәренең авторы. Китап кульъязма күчермәләр рәвешендә татарлар арасында киң таралган була. Иң беренче күчермәләреннән 1698 елда Бимәк суфи тарафыннан күчерелгән нөсхә санала. 1859 да әсәрне Р.*Әмирханов* бастыра. Аннан соң ул Казанда берничә тапкыр нәшер ителә. Мәдрәсәләрдә дәреслек рәвешендә кулланыла. Т.Ялчыгол, Г.Утыз Имәни иҗатларына йогынты ясый.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. 4 том; Каюмова И. Ар-Рабгузи // Ислам на территории бывшей Российской империи: Энцикл. словарь. М., 2001. Вып. 3.

**РАБИГА́ КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама арьягында. Идел елгасының сулъяк яр буе террасасында урнашкан. Спас р-ны Болгар шәһәренең төньяк-көнбатыш чигендә. Су өслегенең мәйданы 2,36 *га*. Су күләме якынча 60 мең $м^3$. Озынлыгы 150 *м*, уртача киңлеге 135 *м*. Уртача тирәнлеге 2,5 *м*, иң зур тирәнлеге 5,5 *м*. Күл карст процессы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы түгәрәк. Ярлары уртача текәлектә, су өслегеннән чама б-н 20 *м* га кадәр биеклеккә күтәрелә, катнаш каен-нарат урманы б-н капланган. Күл төбе комлы. Туенуы тотрыклы, җәен күбесенчә җир асты сулары исәбенә. Күлнең төньяк өлешенә зур сыза тоташа, аның буенча яңгыр һәм кар сулары агып керә. Ял итү максатларында файдаланыла.

**РАБИНО́ВИЧ** Леонид Михайлович (6.3.1934, Одесса ш.) икътисадчы, җир төзү инженеры, икътисад фән. д-ры (1976), проф. (1977), ТАССРның, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1989, 1993), Россиянең мактаулы югары белем бирү хезмәткәре (1993). Пермь а.х. ин-тының җир төзү инженерлары ф-тын тәмамлый (1956). 1956 елдан Казан аграр ун-тында (бүленеп: 1961–66 да Татарстан респ-ка а.х. тәҗрибә станциясенең икътисад һәм җитештерүне оештыру бүлеге мөдире), а.х. икътисады кафедрасын оештыручы һәм аның мөдире (1966–97), проф. (1997 дән), бер үк вакытта (1997 дән) Икътисад, идарә итү һәм хокук ин-тында (Казан) финанс менеджменты каф. профессоры. Хезмәтләрендә Р. колхозчыларны матди кызыксындыруның төрле формалары һәм системасы хуҗалыкның эчке хуҗалык исәбенә туры килергә тиешлеген нигезли. Аның катнашында 1960 елларда эчке хуҗалык исәбе Баулы р-нының «Урал», Азнакай р-нының «Авангард», Нурлат р-нының «Дружба» һ.б. хуҗалыкларында кертелә. Р. эш шартлары буенча бериш а.х. пр-тиеләре өчен икътисади үсеш моделен эшли; хуҗалык итүнең икътисади өлкәсендә яңа фәнни юнәлешкә — планлаштыру, фаразлау, эчке хуҗалык исәбенә, авыл хуҗалыгы б-н идарә итүнең норматив-ресурс ысулына нигез сала. «Татарстан АССРда авыл хуҗалыгы б-н идарә итү системасы» гамәли кулланмасының (1968), игенчелек һәм терлекчелек системалары буенча кулланмаларның авторларыннан берсе. Ф.К.Мусин б-н бергәләп «Дәүләт сатып алуларын (дәүләт заказын) планлаштыру буенча методик тәкъдимнәр» эшли. Ул респ-ка терр-ясендә 1966–90 да гамәлдә була. Агросәнәгать комплексының икътисади проблемаларына караган 30 дан артык китап-брошюра авторы. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Стимулы и резервы эффективности производства. К., 1977; Нормативная основа экономического стимулирования. М., 1989; Хозрасчёт на предприятиях агропромышленного комплекса. К., 2002 (автордаш); Рынок земли: проблемы, поиск, решения. К., 2005 (автордаш); Факторы корпоративной устойчивости. К., 2006 (автордаш).

**«РАБО́ЧАЯ ВО́ЛЯ»** («Эшчеләр иреге»), көндәлек иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. Казан губкомы меньшевиклар партиясе органы. «Рабочее дело» г-тасының дәвамчысы. 1918 елның 28 маеннан 19 июненә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 19 саны чыга. Нашире — С.А.Пионтковский (псевд. «С.П.», «Эспе»), мөхәррире — С.М.Ефимов. Актив авторлар арасында — Җ.Алкин, С.Белов, М.Брук, О.Вегер, А.Визгалик, Б.Горев, С.Казанский, И.Катин, А.Лаптев, Б.Нелидов, Н.Ростов, А.Рясенцев. Шагыйрь С.Лесной шигырьләре басыла. Редакция большевикларга каршы позициядә тора, большевикларны рев-циягә, эшче класска хыянәт итүдә, Гражданнар сугышын башлап җибәрүдә гаепли; газетада Учредительләр җыены чакырылышын хуплауга, гражданлык иреген кире кайтаруга һәм демократик хөкүмәт булдыруга чакырган язмалар басыла. Эшче һәм солдат депутатларының Казан Советы боерыгы б-н ябыла, нашире һәм мөхәррире губерна революцион трибуналы приказы б-н кулга алына. Чех-словак корпусы һәм Халык армиясе частьлары Казанны алганнан соң, газета «Рабочее дело» исеме б-н кабат чыга башлый.

*Әд.:* Мухарямов М.К. Октябрь и национальный вопрос в Татарии. К., 1958; Насыров Т.М. Октябрь и печать Татарии. К., 1975; Литвин А.Л. Пионтковский Сергей Андреевич // Возвращённые имена: Док. очерки. К., 1990.
*Т.М.Насыйров.*

**«РАБО́ЧЕЕ ДЕ́ЛО»** («Эшчеләр гамәле»), көндәлек иҗтимагый-сәяси газета. РСДРП-ның Казан бюросы органы. «*Казанская рабочая газета и известия совета солдатских и рабочих депутатов*» г-тасының дәвамчысы. 1917 елның 9 ноябреннән 1918 нең 18 маена кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 135 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — Б.Н.Нелидов; 1918 нең апреленнән маена кадәр күпчелек саны А.О.Рясенцев редакциясендә чыга. 1918 нең апрелендә өч кушымта саны («Вечерняя газета») басыла. Актив авторлар арасында — М.Борисов, М.Брук, А.Визгалик, Ю.Денике, Г.Кипень, П.Левицкий, С.Маркин, Б.Нелидов, Т.Полюк, Б.Поновецкий, А.Трояновский, Р.Шанин, А.Эрдели. Төп рубрикалары: «Рәсми бүлек», «Партия тормышы», «Эшче тормышы», «Кооператив тормышы», «Сугыш», «Чит илләрдә», «Россия буйлап», «Губерна буйлап», «Икътисади хроника», «Театр һәм музыка». Газета большевикларны Учредительләр җыенын куып тараткан, Брест солыхы төзегән һәм демократик матбугатны эзәрлекләгән өчен тәнкыйтьли. Казан Советы башкарма ком-ты карары б-н ябыла. Соңгы саны «Илне һәм революцияне үлемнән бары бөтен демократиянең берләшүе һәм дустанә иҗади эше генә коткара ала. Социализмга юл демократия аша гына ята. Көч куллану һәм золым бетсен. Бетсен Гражданнар сугышы! Яшәсен Учредительләр җыены!» өндәмәсе б-н чыга. Ябылып ун көн узганнан соң, «Р.д.»ның дәвамчысы — 19 саны чыгуга, ш.у. хөкүмәт тарафыннан ябылган «*Рабочая воля*» г-тасы басыла башлый. 1918 нең җәендә Казан Чех-словак корпусы һәм Халык армиясе кулына күчкәннән соң, «Р.д.» г-тасы Казан меньшевиклар губерна ком-ты органы буларак кабат басыла башлый (1918 нең 9 августыннан 10 сентябренә кадәр чыга; 23 сан, мөхәррире — Б.Н.Нелидов. Газетада яңа рубрикалар барлыкка килә: «Яңа властьның программасы һәм эше», «Халык армиясе фронты». «Халык властен саклау өчен барыгыз да коралга!» дигән өндәмә б-н чыккан соңгы санында меньшевикларның Казан губерна ком-тының һәр эшче «социализм патшалыгына барган юлны чистарткан Халык армиясе сафларына кулга корал тотып кушылырга» тиеш, дигән мөрәҗәгате басыла. Казанны Кызыл Армия алганнан соң, газета басылудан туктый.

*Әд.:* Первый год пролетарской революции: Сб. док. и материалов. К., 1933; Мухарямов М.К. Октябрь и национальный вопрос в Татарии. К., 1958; Насыров Т.М. Октябрь и печать Татарии. К., 1975.
*Т.М.Насыйров.*

**«РАБО́ЧИЙ»** («Эшче»), Казан губернасындагы беренче большевиклар газетасы. РСДРП(б)ның Казан ком-ты органы. 1905 елның 3 июленнән сентябренә кадәр Казан-

да рус телендә яшерен рәвештә басыла, барысы 3 саны чыга; 1908 нең мартында яңадан нәшер ителә, 3 саны дөнья күрә. Басма 1905 нең февралендә Казанга килгән Я.М.Свердлов башлангычы б-н басыла башлый. Газетада большевикларның программасы һәм тактикасы, рев-циядә пролетариат өстенлеге идеясе, эшче сыйныф һәм крәстияннәр берлеген ныгыту мөһимлеге аңлатыла; илнең эре сәнәгать үзәкләрендәге рев-ция вакыйгалары турындагы язмалар даими рәвештә басыла; эшчеләрнең баш күтәрү хәрәкәте, Казан губернасы крәстияннәре арасындагы чуалыш яктыртыла, самодержавие-алпавыт строен бәреп төшерүгә өндәү яңгырый. Материаллар имзасыз басыла, күп кенә мәкаләләрнең авторлары, фаразланганча, большевикларның Казан ком-ты әгъзалары В.В.Адоратский һәм Н.Н.Накоряков була. 1908 дә яңадан чыгара башлау Казан большевикларының революцион хәрәкәтнең кимүе шартларында халык арасында пропаганда алып бару теләге б-н аңлатыла. Беренче санның «Агымдагы мизгел һәм безнең мәсьәләләр» дигән баш мәкаләсе: «рев-ция дәвам итә»; большевиклар нәкъ менә коммунистлар партиясе Россия пролетариатын оештыручы төп көч булып тора, дип ассызыклый; Казан ком-ты эшчеләргә РСДРПның унъеллыгын бәйрәм итү мөрәҗәгате б-н чыга. Газета эшчеләрне актив хәрәкәткә һәм самодержавиегә каршы көрәшне дәвам итәргә чакыра, укучыларын II Интернационалның Штутгарт конгрессы йомгаклары, РСДРП(б) ҮКның «Профессиональ союзлар турында»гы резолюциясе, ҮКның «3 нче Дәүләт Думасында социал-демократик фракция эшчәнлеге турында»гы хаты б-н таныштыра. «Православие чиркәве нәрсә ул» («Что такое православная церковь»), «Христианлык һәм социализм» («Христианство и социализм») дигән мәкаләләр дини иллюзияләргә, христианлык б-н социализмны берләштерүгә омтылуларга каршы юнәлдерелгән.

*Әд.:* Н а ф и г о в Р.И. Казанская социал-демократическая организация в 1907–1914 гг. К., 1961; М у л л и н а Л.Б. Печать Казанских большевиков в 1905 г.: Дис. ... К., 1966; Очерки истории партийной организации Татарии. К., 1973.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«РАБО́ЧИЙ»**, газета, к. *«Республика Татарстан»*.

**«РАБО́ЧИЙ ХИ́МИК»** («Эшче химик»), тармак журналы. Бөтенроссия эшче-химиклар берлегенең Татарстан өлкә бүлеге (БЭХБТӨБ) органы. 1922 елның маеннан октябренә кадәр Казанда рус телендә басыла, барысы 5 саны чыга. Журнал БЭХБТӨБ идарәсе тарафыннан нәшер ителә һәм редакцияләнә. Мәкаләләр ТАССРның химия сәнәгате үсешенә, тармакның аерым заводлары (Бондюг, Казан дары, Кокшан һ.б.) хәленә багышлана. Пр-тиеләрдә фабрика-завод ком-тлары эшен оештыру, тариф-икътисад сәясәте, хезмәтне саклау, хезмәт дисциплинасы сорашы, социаль имиятләштерү мәсьәләләре җентекләп яктыртыла. БЭХБТӨБнең җирле бүлекләре һәм үзәк органнарның карарлары басыла, 5 нче санда Татарстанның химия сәнәгате эшче һәм хезмәткәрләренең 4 нче өлкә съезды материаллары дөнья күрә. Редакция тармак хезмәткәрләренең ашханәләре, балалар бакчалары, эшче клублары, ял йортлары эшчәнлеген күзәтә. Химия сәнәгате кадрларының проф.-техник белемен, квалификациясен күтәрү, мәдәни-агарту эшен җайга салу мәсьәләләре еш күтәрелә.

*Р.А.Айнетдинов.*

**РАВИ́ЛЕВ** Габделхәмит Зариф улы (15.10.1932, Казан), вет. вирусологы, вет. фән. д-ры (1977), проф. (1983), ТАССРның, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1983, 1990), ТР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1995). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), Аксубай р-нының «МЮД» дуңгыз үрчетү с-зында баш вет. табибе булып эшли. 1964 елдан Казан вет. ин-тында: өлкән фәнни хезмәткәр, вирусология лаб-ясе мөдире. 1984 тән Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында: директор (2004 кә кадәр), вирусология лаб-ясе мөдире (2007 гә кадәр). 2007 дән «Россельхознадзор»ның «Татарстан төбәкара ветеринария лабораториясе» федераль дәүләт учреждениесе фәнни консультанты. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре вируслы һәм хламидиозлы инфекцияләргә диагноз кую өчен препаратлар уйлап табуга, гамәли вет. һәм мед. сәнәгате өчен норматив-техник документлар эшләүгә карый. Уйлап табуга 58 авторлык таныклыгы һәм 8 патенты бар. ТР Дәүләт премиясе лауреаты. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Хламидиозы сельскохозяйственных животных. М., 1984 (автордаш); Ветеринарная радиоэкология. К., 2000 (автордаш); Патоморфогенез сибирской язвы. М., 2002 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006). К., 2006.

**РАВИ́ЛЕВ** Рөстәм Хәмит улы (28.9.1963, Казан), вет. эпизоотологы, вет. фән. д-ры (1999), проф. (2000), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1985). 1987 елдан Казан вет. медицинасы академиясендә: ассистент, өлкән укытучы, вак хайваннар патологиясе (1999–2005) һәм эпизоотологиясе (2005 тән) кафедралары мөдире, бер үк вакытта стандартлаштыру һәм сертификацияләү ф-ты деканы (2001–04), 2016 дан ректор. Фәнни-тикшеренү эшләренең юнәлеше — ерткыч хайваннардагы хламидиоз авыруын алдан кисәтү һәм дәвалау, диагностиканың яңа чараларын эзләү. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Р. диагностик җыелмалар, терапевтик биопрепаратлар, вакциналар эшләүдә катнаша.

Х е з м.: Хламидиоз животных. К., 2004; Хламидиоз собак и кошек. М., 2006; Токсоплазмоз домашних плотоядных животных. К., 2008 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006). К., 2006.

**РА́ГИНОВ** Иван Сергеевич (8.9.1974, Казан), нейрогистолог, мед. фән. д-ры (2007). Казан мед. ун-тын тәмамлаганнан соң (1997), шунда ук, гистология кафедрасында эшли. 2002–04 елларда Португалия һәм Германия нейробиол. үзәкләрендә фәнни командировкада була. Хезмәтләре периферик нерв системасы регенерациясенә, тычканнарда утракса нервының травмадан соңгы регенерациясендә транстиретинның ролен өйрәнүгә карый. «Периферик нервның травмадан соңгы регенерациясен күзәнәк технологияләре кулланып стимуллаштыру» хезмәте өчен — РФ Президенты бүләге (2006), «Нейраль кәүсә күзәнәкләр трансплантациясе шартларында күседә утракса нервының травмадан соңгы регенерациясе» фундаменталь хезмәте өчен ТР ФА бүләге (2006) бирелә.

Х е з м.: Роль транстиретина в посттравматической регенерации седалищного нерва мыши // Морфология. 2004. Т. 126, № 6; Выживание и фенотипические характеристики аксотимированных нейронов в спинальных ганглиях // Нейронаучный журн. поведенческой физиологии. 2005. Т. 35, № 5; Эффект ксимедона на кальциевые токи в пирамидных нейронах энторинального кортекса // Эксперим. и клинич. фармакология. 2006. Т. 69, № 1.

**РАГО́ЗИНО** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Пакшин елгасы буенда. 2010 елда 152 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп-балалар бакчасы, клуб, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Р.да чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 971 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Троица-Сәкинәс волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 174 ир-ат; 1859 да — 597, 1897 дә — 786, 1908 дә — 1006, 1920 дә — 940, 1926 да — 1050, 1938 дә — 934, 1949 да — 455, 1958 дә — 411, 1970 тә — 373, 1979 да — 307, 1989 да — 378, 2002 дә — 255 кеше.

**РА́ДБИЛЬ** Оскар Самойлович (27.8.1919, Киев — 18.3.1993, Мәскәү), терапевт, мед. фән. д-ры (1960), проф. (1962), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1970). 1941 елда Киев мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, 1942–46, 1957–73 тә Казан ГИДУВында эшли, 1957 дән 2 нче терапия каф. мөдире; 1946–56 да (бүленеп) СССР МФАнең дәвалау туклануы клиникасында, Витаминология ин-тында, Бөтенроссия дару һәм хуш исле үләннәр фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү). 1973–88 дә СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Бөтенсоюз мед. мәгълүматы фәнни-тикшеренү ин-тында бүлек мөдире. Хезмәтләре гастроэнтерологиягә, ашказаны җәрәхәтен, бавыр һәм үт юллары хроник авыруларын өйрәнүгә карый. Совет эндокрин гастроэнтерологиясенә нигез салучыларның берсе.

Х е з м.: Кора надпочечников и язвенная болезнь. К., 1967 (автордаш); Болезни желудка. К., 1971 (автордаш); Эндокринная система и желудок. К., 1973 (автордаш); Фармакологические основы лечения болезней органов пищеварения. М., 1976.

*Әд.:* Памяти Оскара Самойловича Радбиля // Терапевт. архив. 1993. № 12.

*В.Ф.Богоявленский.*

**РАДЗИЕ́ВСКАЯ** Софья Борисовна (12.6.1892, С.-Петербург — 17.7.1989, Мәскәү), язучы. Петроградта Бестужев Югары курсларын тәмамлый (1918). Урта Азиягә, Себер, Манчжурия, Урал, Кавказга экспеди-

цияләрдә катнаша. Ташкентта үсемлекләрне саклау ин-тында (1925–33), Мәскәүдә СССР Җир эшләре халык комис-тында эшли (1934–36). 1937 елдан Казанда: элеваторда, азык-төлек складларында инспектор-энтомолог (1937–42), 1944–49 да җитештерү өлкәсендә химик булып эшли. 1950–58 дә Респ-ка лекцияләр бюросында методист, Казан ун-ты фәнни китапханәсенең кульязмалар бүлеге мөдире. 1986–88 дә Севастопольдә, 1988 дән Мәскәүдә яши. Китапларының күп өлеше балалар өчен язылган (төп тема — табигать). «Хайваннар турында хикәяләр» («Рассказы о животных»), «Пуш» (икесе дә Таш., 1932), «Сазлык Робинзоннары» («Болотные Робинзоны», 1959), «Алтын эзләп» («За золотом», 1962), «Балалар, сезнең өчен!» («Для вас, ребята!», 1965), «Пум» (1966), «Рам һәм Гау» («Рам и Гау», 1967), «Батырлык утравы» («Остров мужества», 1969), «Буй-буй сырт» («Полосатая спинка», 1979) һ.б. китаплар авторы. Р.ның хикәя һәм повестьлары үсемлекләр, хайваннар, төрле табигать күренешләре турында мавыктыргыч бай мәгълүмат бирә. Халыклар дуслыгы ордены б-н бүләкләнә (1982).

Ә с ә р.: Избранное. К., 1972; Повести и рассказы. К., 1982.

*Әд.:* И х с а н о в а Л. Олы бәхет иясе: Софья Радзиевскаяга 90 яшь // Казан утлары. 1982. № 6; А х у н о в Г. Родник добра: К 90-летию со дня рождения С.Б.Радзиевской // Лит. Россия. 1982. 2 июля. *Р.Р.Мусабәкова.*

**РАДИ́МОВ** Павел Александрович (11.9.1887, Рязань губ., Зарайск өязе Ходяйново а. — 12.2.1967, Мәскәү өлкәсе Хотьково ш.), нәкышьче, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе. Зарайск руханилар уч-щесендә, Рязань руханилар семинариясендә укый. 1905 елда Мәскәүдә Большаков студиясендә нәкышь дәресләре ала. 1906–31 дә — Казанда (бүленеп). 1911 дә Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлый. 1912–23 тә Казан сәнгать мәктәбендә сәнгать тарихын укыта. 1918–22 дә ТАССР Халык Мәгарифе комиссариатында сынлы сәнгать бүлеге инструкторы һәм мөдире була, Казанда Беренче түләүсез картиналар күргәзмәсен оештыра. АХРРны оештыручылардан һәм әгъзаларыннан берсе (1922), ТатАХРРның 1 нче рәисе (1923). Күчмә сәнгать күргәзмәләре ширкәте әгъзасы һәм рәисе (1914; И.Е.Репин һәм В.Д.Поленов тәкъдимнәре буенча кабул ителә). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1933). Р. Казан һәм Идел буе шәһәрләренең сәнгать тормышына лаеклы өлеш кертә. 1922 дә Мәскәү өлкәсенә барып урнаша. Ил буйлап иҗади сәфәргә чыга: Төркмәнстанда, Белоруссиядә, Үзбәкстанда, Чувашиядә була. А.В.Луначарский, М.В.Фрунзе, С.М.Будённый, К.Е.Ворошилов портретларын иҗат итә. Нәкышь өлкәсендә соңгы чор «күчмәлек» традицияләре юнәлешен яклый. 1910–20 елларда Р. иҗатында халык образлары, бәйрәмнәре һәм гореф-гадәтләре темасы өстенлек итә; әсәрләре көнкүрештәге этнографик детальләрнең ачык, бай колоритлы төгәл күчермәсе буларак аерылып торалар: «Мичкә ясаучы», «Казан янындагы Кокушкино авылы», «Өйдә», «Эстәрлетамак янындагы Башкорт иле» (барысы да — 1910 елларда). Казан чорында — «Кечкенә ишегалды» (1919), «Татар ишегалды» (1920) пейзажлары, «Кое янында», «Татар малае», «Көтүче татар» (1922–27), «Татар авылы» (1915), «Чыптага төренгән кешеләр» (1922–27) жанрлы картиналары языла. Р. — совет тематик картиналар жанрына нигез салучыларның берсе, сәяси тормыш, Гражданнар сугышы, Идел буендагы ачлык, ТАССРда һәм Мари автономияле округында колхозлар, фабрикалар оештыру темаларына әсәрләр иҗат итә: «Коминтернның



П.А. Р а д и м о в. «Кечкенә ишегалды». «Мари этюдлары» сериясеннән. 1919. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

II конгрессында Троцкийның чыгышы», «Коминтернның соңгы конгрессында В.И.Ленинның чыгышы» (икесе дә — 1927), «Хоровод» картинасына Казан янындагы Щербаковка авылында язылган этюдлар (1928). 1930 еллардан башлап, Урта Азиягә, Россиянең Урта полосасына, Мәскәү өлкәсенә багышланган пейзажлар циклын иҗат итә: «Абрамцево» (1932), «Аннаудагы мәчет» (1934), «Хива дәрвише», «Фирүзәдә таң ата» (икесе дә — 1935), «Троица-Сергий лаврасы» (1944), «Ясная Полянадагы Волконский йорты» (1952) һ.б. 1912 дә Р. шагыйрь буларак чыгыш ясый; аның шигъри таланты А.М.Горький, В.Я.Брюсов, Н.С.Гумилёв тарафыннан билгеләп үтелә. Р. шигъриятендә Россия авылы, тасвирлы пейзаж лирикасы өстенлек итә («Болын аятьләре», 1912; «Җир чапаны», 1914 һ.б. җыентыклар).

Казан рәссамнары (1908 дән), Күчмә сәнгать күргәзмәләре ширкәте (1912 дән), АХРР (1922 дән), совет сәнгатенең чит илләрдәге (Венеция, Лондон, Берлин, Мюнхен, Кёльн, Стокгольм, Нью-Йорк шәһәрләре) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1933 һәм 1962 дә уздырыла (Мәскәү).

Р.ның әсәрләре Третьяков галереясендә, Рус музеенда, Россия СА музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Чуаш сәнгать музеенда, Луганск сәнгать музеенда (Украина), шәхси тупланмаларда саклана. Р. портретларын Н.И.Фешин, Л.Пузовкин ясый.

Х е з м.: Старик и липа, или Отчего по свету пошли медведи: Вотская сказка. К., 1922; Телега. М., 1926; Ливень: стихи и пейзажи. М., 1962; О родном и близком. М., 1973.

*Әд.:* П е р е л ь м а н В.Н. Живопись П.А.Радимова. М., 1926; Г л и н к и н М.Д. П.А.Радимов. М., 1960; К л ю ч е в с к а я Е.П. Изящные искусства в Казанском университете. К., 2008. *Е.П.Ключевская.*

**РАДИОМЕТЕО́Р АСТРОНО́МИЯСЕ**, астрономия һәм радиофизиканың Җир атмосферасына килеп кергән космик җисемнәрнең плазмалы (ионлашкан) эзләрен радиоалымнар (радиолокация һәм ионосфераны авыш зондлау) ярдәмендә тикшерә торган бүлеге. Радиолокаторлар өчен — 25–41 *МГц* диапазонындагы, метеор-ионосфера радиотрассалары өчен 8–45 *МГц* диапазонындагы радиоешлыклар иң нәтиҗәле үлчәү ешлыклары булып санала. Р.а. космик кисәкчәләрнең (радиантларның) массасы, тизлеге, килү юнәлеше турында мәгълүмат алу мөмкинлеге бирә. Атмосферадагы ионлашкан метеор эзләрен радиолокацион күзәтүләрне СССРда беренче булып Казан ун-тында К.В.Костылёв үткәрә (1955). Метеор радиолокаторында (Ю.А.Пупышев) һәм авыш зондлау алымы б-н (Н.С.Андрианов) Казан ун-тында алып барылган күпьеллык үлчәүләр радиантларның (аерым кисәкчәләр һәм аларның ассоциацияләренең дә, метеор агышларының да) күк сферасындагы бүленешен өйрәнү мөмкинлеген бирә. Бу нәтиҗәләр астрономия өчен генә түгел, космонавтика үсеше өчен дә мөһим, чөнки алар космик аппаратларның төрле үлчәмдәге төрле массалы микрометеоритлар б-н очрашу ихтималын космик аппарат орбитасының кайда булуыннан чыгып бәяләргә ярдәм итә (О.И.Белькович). Җир атмосферасына югары тизлек б-н (дистәләрчә *км/с*) килеп кереп, метеор кисәкләре 75–105 *км* биеклектә берничә дистә *км* озынлыктагы беренчел туры һәм ионлашкан эзләр калдыра, бу эз уртача атмосфера җиле б-н күчә һәм турбулентлык тәэсирендә кәкрәя. Ешлыкның доплерча күчеше һәм амплитуда-вакыт характеристикасы вариантлары бирелгән биеклекләрдә атмосфера һәм ионосфера характеристикалары турында мәгълүмат бирә. Казан ун-ты астрономнарының хезмәтләре бу биеклекләрдә атмосфера циркуляциясенең дулкынча һәм турбулент вариацияләрен (Г.М.Тептин, Г.Б.Покровский, А.Н.Фәхретдинова), түбәнге ионосфераның электрон турбулент концентрациясенең спектраль һәм структур характеристикаларын (Г.М.Тептин, Ю.М.Стенин) өйрәнү мөмкинлеген бирә, шулар нәтиҗәсендә төрле кулланылыштагы метеор-ионосфера радиотрассаларының төп үзлекләрен билгеләү һәм аларны ышанычлы фаразлау башлана (Р.А.Курганов). Алынган нәтиҗәләр (метеор җисемнәрнең астрономик аспектларын да кертеп) метеор радиоэлемтәсе мәсьәләләрен хәл итү (К.В.Костылёв) һәм төгәл вакытны тапшыру өчен (В.В.Сидоров) кулланыла.

*Әд.:* К о с т ы л ё в К.В. Астрономические основы метеорной радиосвязи. К., 1970; Б е л ь к о в и ч О.И. Статистическая теория радиолокации метеоров. К., 1971; К у р г а н о в Р.А. Прогнозирование наклонного рассеяния радиоволн метеорными ионизациями. К., 1973; Т е п т и н Г.М. Структура нижней термосферы. К., 1976; T e p t i n G.M., S t e n i n Yu.M. Inhomogeneous structure of lower ionosphere and radio wave propagation. K., 2007. *Г.М.Тептин.*

**«РАДИОПРИБО́Р»**, төрле радиоэлектроника системаларын проектлау, җитештерү, файдалануда хезмәт күрсәтү һәм төзекләндерү б-н шөгыльләнүче пр-тие. 1940 елның декабрендә Мәскәү пластмасса з-ды (294 нче з-д) буларак нигезләнә. 1941 нең ахырында Казанга эвакуацияләнә (1942–44 тә — 22 нче авиация з-ды ф-лы). 1949 дан п/я 423 пр-тиесе; 1966 дан хәзерге исемдә; 1970–92 дә составына Әлмәт (1967 дә нигезләнә) һәм Лениногорск (1969) шәһәрләрендәге приборлар төзү з-длары кергән Татарстан «Р.» ҖБ; 1992 дән дәүләт пр-тиесе; 1999 дан дәүләт унитар пр-тиесе. 2000 дә акционерлаша һәм «Аэрокосмик җиһазлар» корпорациясе» АҖ составына керә, 2009 дан «Россия технологияләре» дәүләт корпорациясенең «Радиоэлектроника технологияләре» концерны составында.

Бөек Ватан сугышы елларында завод самолётлар өчен текстолит детальләр, халык куллануы товарлары (савыт-саба, уенчыклар, төймәләр) эшләп чыгара. Алдагы чорда үзгәртеп корыла, авиация радиолокацион тану (1949), якын арадагы навигация һәм җиргә утырту (1958) системалары, антенна-фидер җайланмалары (1963), телевизорлар, күчерелмә радиолалар, радиола-магнитофоннар, көчәнеш стабилизаторлары (1950–60 еллар), телевизион приставка-селекторлар, антенналар һәм кабул итү көчәйткечләре (1979–82), самолётларның автомат режимда очышын һәм аларны җиргә утыртуны исәпләү өчен борт хисаплау машиналары (1983; аларның бер модификациясе күп файдаланулы «Буран» космик корабленда кулланыла, 1988) җитештерүне үзләштерә. Беренче эшләнмәләр лампалы схемалар б-н чыгарыла (1 нче буын), 1960–70 елларда алар модульләр һәм микромодульләр рәвешендә коелма платаларда җитештерелә башлый (2 нче һәм 3 нче буыннар). Яңа продукция чыгаруны үзләштерү пр-тие мәйданнарын киңәйтү (1960 ка 7 тапкыр диярлек), махсуслаштырылган кою-механика производствосын төзү (1970 еллар ахыры), Казан фәнни-тикшеренү радиотехнол. ин-тын оештыру (1978), автоматлаштыру һәм механикалаштыру чараларын, ш.и. механикалаштырылган линияләр, роботлар, манипуляторлар, соңрак тармакның башка пр-тиеләрендә дә киң таралган «Ритм» җитештерүне автоматлаштырылган идарә системасын (1970–80 еллар) эшләү һәм гамәлгә кертү б-н бергә алып барыла. 1940–80 елларда эшләүчеләр саны 500 дән 10 мең кешегә кадәр арта. «Р.» ҖБ илдә әйдәп баручы авиация радиотехникасы аппаратларын җитештерүчеләрнең берсенә әверелә. 1980 еллар ахырыннан, төп продукциягә дәүләт заказлары кимү шартларында, сәнәгый-техник приборлар, автомобиль компонентлары, халык куллануы товарлары һ.б.ны эшләү һәм җитештерү гамәлгә ашырыла.

Төп (җыю-монтаж, механика, кою, штамповкалау, гальваника, инструментлар, лак-буяу, коелма платалар) җитештерүдә һәм «Р.»ның башка подразделениеләрендә 1,7 мең кеше эшли (2010). Продукциянең гомуми күләменең 80% тан артыграк өлешен Россиядә һәм якын чит илләрдә җитештерелгән күпчелек самолётларда, вертолётларда куела торган һәм дөньяның 30 дан артык илендә файдаланылучы борт авиация радиотехникасы комплекслары тәшкил итә. Җитештерү күләменең 18% тан артыграк өлеше җылылык энергетикасында, химия, металлургия һәм нефть-газ чыгару сәнәгатендә кулланыла торган контроль һәм саклау, технол. процесслар һәм җиһазларны автоматлаштырылган идарә итү микропроцессорлы җайланмаларына туры килә. Автомобильләр төзелеше өчен тормоз системалары, тапшыру тартмалары узеллары, артка чигенү сигнализаторлары,



«Радиоприбор» АҖнең завод идарәсе. Казан.

көзге детальләре чыгарыла. Бронетанк техникасы өчен тележылылык автоматлары, автомобиль компьютерлары һ.б. приборлар җитештерү үзләштерелә. Авиация техникасында куллануны киңәйтү өчен җитештерелә торган авиация җиһазлары камилләштерелә. Продукцияне эшләү һәм камилләштерүдә пр-тие «Радиоэлектроника» федераль фәнни-җитештерү үзәге (к. *Казан радиоэлектроника институты*), Казан техник ун-ты, РФА КГҮнең Казан физика-техника ин-ты, С.-Петербург, Таганрог һ.б. шәһәрләрнең фәнни-конструкторлык оешмалары б-н тыгыз хезмәттәшлек итә. Комплектлаучы детальләр һәм материаллар Казан, Сарапул, Новосибирск, Каменск-Уральский, Зеленоград, Пенза, Минск һ.б. шәһәрләр компанияләреннән кiтерелә. «Р.»ның җитештерүдәге казанышлары «Почёт билгесе» ордены (1976), КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС, ВЛКСМ ҮК, СССР Радиосәнәгать министрлыгы һ.б.ның дипломнары, грамоталары, күчмә Кызыл байраклары б-н билгеләп үтелә, 400 дән артыграк хезмәткәре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. Соц. Хезмәт Герое исеме — 1, СССР Дәүләт бүләге — 2, ТР Дәүләт бүләге — 1, Ленин ордены — 11, Октябрь Революциясе ордены — 7, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены — 62, Халыклар дуслыгы ордены — 1, «Почёт билгесе» ордены — 75, 2 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» ордены — 5, 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» ордены 68 кешегә бирелә.

Пр-тие директорлары: Ф.С.Малахов (1941), И.П.Младенцев (1941–42), С.Д.Макаров (1942–44), В.Ф.Прохоров (1944–46), И.М.*Шпаков* (1946–59), М.С.Огородников (1959–62), В.И.Самарин (1962–66), Ю.Ф.Җамалетдинов (1966–94), Р.У.*Апаков* (1994–2009), Р.Н.Шәрипов (2009 дан).

*С.Г.Белов.*

**РАДИОТЕЛЕГРА́Ф ОЕШМАЛАРЫНЫ́Ң КАЗА́Н БА́ЗАСЫ**, Кызыл Армиянең радио белгечләрен укыту һәм радиоэлемтә чараларын әзерләү өчен оештырылган бүлекчәсе. Ил күләмендә андый базалар Владимир, Саратов, Тверь шәһәрләрендә төзелгән була. 1919 елның 17 апрелендә Саратов шәһәрендә оештырылган база, шәһәргә Ак армия частьлары һөҗүме сәбәпле, Казанга күчерелә һәм 1 сентябрьдән 2 нче Р.о.К.б. дип атала башлый. Радиобаза шәһәрнең иске өлешендәге Новиковлар дачасында (хәзер Н.Ершов урамы) урнаша һәм 1923 кә кадәр эшли. Ул укыту-тәҗрибә радиостанциясе булган лаб-ядән, радиотелеграфистлар әзерли торган радио мәктәбеннән, оешмаларның дивизионыннан, радиостанцияләр төзәтү һәм җыю остаханәләреннән тора. Р.о.К.б.ның эше Мәскәүдән Ходынка тапшыру станциясеннән Морзе коды б-н җибәрелгән радиотелеграммалар кабул итүче 1 нче *Казан радио кабул итү-тапшыру станциясе* эшчәнлеге б-н килешенеп алып барыла. Базаның башлыгы итеп радиоинженер-сынаучы А.Т.*Углов* билгеләнә; базада радио белгечләре А.В.*Дикарёв*, С.К.Папазов, Н.Чистов һ.б. эшли. Р.о.К.б.да сүнми торган тирбәнешләрнең лампалы тапшыргычларын куллануга нигезләнгән радиотелефон элемтәсенең һәм тавышны үткәргечләр буйлап тапшыруның илкүләм башлангычын тәшкил иткән тикшеренү һәм конструкторлык эшләре алып барыла. А.Т.Углов һәм З.В.Виткевич схемалары буенча (1920) 1 мең *Вт* егәрлекле бер каскадлы 10 лампалы тапшыргыч конструкцияләнә. Беренче радиотапшыруларның радиосигналларын 65 *км* га, ә көчәйткечләр б-н 200 *км* га кадәр кабул итәргә мөмкин була. 1921 дә сүнми торган тирбәнешләрнең радиотелефон һәм радиотелеграф режимнарында 1500 *м* озынлыктагы радиодулкыннар б-н эшли торган 100 лампалы тапшыргыч булдырыла. Бу тапшыргыч югары ешлыклы тирбәнешләрне көчәйтүче 3 каскад б-н эшли, алар пароходларга куелган радиостанцияләр аша Идел буе шәһәрләре б-н радиоэлемтә тәэмин итәләр. Югары ешлык генераторларын (к. *Дикарёв көчәйткече*) куллану радиотелеграф техникасына керткән зур өлеш була. 1919–20 дә Дикарёв системасындагы 6 һәм 9 лампалы көчәйткечләр һәм 12 лампалы өч каскадлы Углов конструкциясендәге түбән ешлыклы көчәйткеч (30 *Вт* егәрлек бирүче) эшләнә. 1920 дә Р.о.К.б.да В.И.Баженов, Л.В.Виткевич һ.б. системасындагы 9 радиопеленгатор станциясе эшләп чыгарыла;



Радиотелеграф оешмаларының 2 нче Казан базасы бинасы.

аларга куелган 6 лампалы көчәйткечләр 600 *км* га кадәр ераклыктагы дошман радиостанцияләрен табу мөмкинлеген бирә. Казан базасы Татарстанда гражданнар радиоэлемтәсен булдыруга зур йогынты ясый. 1920 дә ул хөкүмәт телеграммаларын кабул итә һәм тапшыра башлый; Уфа, Сембер, Оренбург, Чиләбе, Вятка, Түбән Новгород, Саратов шәһәрләре б-н радио элемтәсен урнаштыра. 1921 дән армия радиостанциясе тулаем Почта һәм телеграф халык комис-тына, гражданнар оешмалары һәм халык карамагына күчә. 1920–21 дә респ-каның Арча, Мамадыш, Кама Тамагы, Чистай, Лаеш, Минзәлә, Богородский, Зөя, Буа, Биләр, Тәтеш торак пунктларында кабул итүче радиостанцияләр эшли башлый; ТАССРның Почта һәм телеграф идарәсе составында радиотелеграф бүлекчәсе оештырыла, радио курслары ачыла. 1920 еллар башында Казанда Радио дуслары җәмгыяте барлыкка килә; җәмгыять әгъзалары П.Я.Ключевский, В.М.Тимофеев, И.М.Романов, Ш.Х.*Усманов*, В.М.Дюков, А.Н.Плясов һ.б. радиоалгычлар, көчәйткечләр, радиоҗайланмалар әзерләү б-н шөгыльләнәләр, шәһәрдә радио элемтәсен оештыру эшендә башлап йөриләр (к. *Татарстан Республикасында радиотапшырулар*).

*Әд.:* Орлова А.Ф. Время и связь. К., 1988; Айтуганова М. Первые опыты радиовещания в Татарстане // Тыңлагыз, Казан сөйли! — Слушайте, говорит Казань! 1927–1997. К., 1998; Милицын Б. Радио и время // Респ. Татарстан. 2000. 10 июня; Залялов Р.Г. Людей связующая нить. К., 2003.

*Б.Р.Милицын, Е.А.Стахов.*

**РАДИОЭЛЕКТРО́НИКА**, фән һәм техниканың мәгълүматны электромагнетик дулкыннар куллану нигезендә тапшыру, кабул итү һәм үзгәртү мәсьәләләре б-н бәйләнгән өлкәләре комплексын берләштерүче термин; үз эченә радиотехниканы, электрониканы, ш.у. аларның үсеше һәм дифференциациясе нәтиҗәсендә бүленеп чыккан яңа өлкәләрне: квант, ярымүткәргечләр электроникаларын, микро-, нано-, опто-, акусто-, криоэлектрониканы, *инфракызыл техниканы*, хемотрониканы һ.б.ны ала. «Р.» термины 20 йөз урталарында барлыкка килә. Р. радиофизика, каты җисем физикасы, *оптика*, механика, электротехника, автоматика һәм *техник кибернетика* б-н үзара бәйләнгән. Р. алымнары һәм чаралары хәзерге заман техникасының күп кенә өлкәләрендә, халык хуҗалыгында, медицинада һ.б.да кулланыла. Радиоэлектрон элементлар *элемтә*, телекоммуникацияләр, автоматлаштырылган идарә, *хисаплау техникасы, мәгълүмат технологияләре*, үлчәү һ.б. приборлар системаларының әһәмиятле состав өлеше булып тора.

1899 елда Казан инженеры А.А.Полумордвинов сурәтләрне электр сигналлары б-н тапшыруга патент ала. 1919–23 тә *радиотелеграф оешмаларының Казан базасында* төрле радиоҗайланмалар эшләү алып барыла, ерак элемтә (1100 *км* га кадәр) радиотелефоннары, радиопеленгатор станцияләре (600 *км* га кадәр), А.Т.Угловның поездлар һәм пароходлар б-н элемтә өчен очкынлы һәм радиотелефон станцияләре конструкцияләнә. 1921 дә Казанда, илдә беренче тапкыр, урамнарга репродукторлар куела һәм радиотапшырулар трансляцияләнә. Россия Р.сына нигез салучыларның берсе — В.А.*Котельников.* Квант электроникасы барлыкка килүдә һәм аның үсешендә Е.К.*Завойский*ның 1944 тә *электрон парамагнетик резонанс* күренешен ачуы зур роль уйный. Р.Ш.Нигъмәтуллин беренче тапкыр (1962) электрохимик мәгълүмат үзгәрткечләр нигезендә вакланмалы интеграллаштыруга һәм дифференциаллауга ирешә һәм шуның б-н фракталь радиоэлектроника барлыкка килүгә зур өлеш кертә. Казанның югары уку йортларында һәм фәнни-тикшеренү оешмаларында Р. өлкәсендә тикшеренүләр башлана һәм зур фәнни юнәлешләр билгеләнә: радиолокацион метеорлар астрометриясе һәм радиоэлемтә (К.В.Костылёв, В.В.Сидоров, 1957), электрохимик мәгълүмат үзгәрткечләр (Р.Ш.Нигъмәтуллин, В.А.Белавин, М.Р.Вяселев, 1953), *антенналар* синтезы теориясе (В.И.Поповкин, 1964), гибрид микросхемалар (Ю.П.Ермолаев, 1963) һәм лазерлар (Ю.Е.Польский, 1969) булдыру һәм куллану, *полигаусс процесслары* һәм статистик радиотехника алымнары (Ш.М.Чабдаров, 1972), ярымүткәргечләр модификацияләүнең ион-импульслы алымнары (И.Б.Хәйбуллин, 1972), телекоммуникацияләр теориясе һәм техникасы (А.Ф.Надеев, 2001).

ТРда авиация һәм диңгез суднолары өчен радиолокацион дәүләт тануы системаларын эшләү һәм җитештерү буенча илдәге иң эре комплекс барлыкка килә; аңа Федераль «Радиоэлектроника» фәнни-җитештерү үзәге (к. *Казан радиоэлектроника институты*), «*Радиоприбор*» һәм «Әлмәт «Радиоприбор» заводы» АҖләре һәм Казан электротехника з-ды (к. «*Свияга*») керә. Шулай ук ТР Фәннәр академиясендә, РФА КГҮнең *Казан физика-техника институтында*, «ГИПО» ФҖБдә (к. *Гамәли оптика институты*), *Казан оптика-механика заводында*, Чистайның «Вектор» КБсында, «Элекон» з-дында һ.б.да фәнни тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык эшләре һәм радиоэлектрон җиһазлар җитештерү гамәлгә ашырыла. Р. б-н бәйле белгечлекләр буенча укыту Казан техник ун-тында, Казан (Идел буе) Федераль ун-тында, Казан энергетика ун-тында, Казан элемтә электротехникумында, Казан авиация техникумында, машиналар төзү буенча укыту кластеры составына кергән һөнәри белем учреждениеләрендә алып барыла.

*Әд.:* Родионов В.М. Зарождение радиотехники. М., 1985; Формирование радиоэлектроники. М., 1988; Современная радиоэлектроника (50–80-е гг.). М., 1993; Бойко Б.П. Основы радиоэлектроники: В 2 ч. К., 2001–06; Застела М.Ю. Основы радиоэлектроники и связи. К., 2005; Быховский М.А. Пионеры информационного века: История развития теории связи. М., 2006; Потапов В.А., Гильмутдинов А.Х., Ушаков П.А. Фрактальные элементы и радиосистемы. Физические аспекты. М., 2009.

**«РАДИОЭЛЕКТРО́НИКА»**, к. *Казан радиоэлектроника институты.*

**РАДИ́ЩЕВ** Александр Николаевич (20.8.1749, Мәскәү — 12.9.1802, С.-Петербург), революцион фикер иясе, язучы. Татар бәге Кунай нәселеннән. «Иреклелек» («Вольность», 1783), «Ф.В.Ушаков тормышы» («Житие Ф.В. Ушакова», 1789), «Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт» («Путешествие из Петербурга в Москву», 1790) әсәрләрендә патша хакимиятен һәм крепостной хокукны тәнкыйть итә. 1790 елда



А.Н. Радищев.

Себергә (Илим төрмәсе) сөрелә. Сөргенгә барышлый һәм кайтышлый Идел һәм Кама буйлап Пермь аша бара. Юлда алган тәэсирләре «Себергә сәяхәт язмалары» («Записки путешествия в Сибирь», 1906 да басыла), «Себердән сәяхәт язмалары» («Записки путешествия из Сибири», 1797, 1907 дә басыла) китапларында чагылыш таба. Беренче китабында Вятка елгасы, Арча, Казан шәһәрләре, татарлар һ.б. Идел буе халыклары турында мәгълүмат урнаштырылган, икенчесендә Алабуганың истәлекле урыннары (Шайтан каласы), «юлда очраган табигать матурлыклары» («Осланда: кичкә таба биек тауга мендек, аннан бик матур манзара ачыла») җентекләп тасвирлана, 1797 нең 25 маеннан 9 июненә кадәр Казанда булып, анда алган тәэсирләре б-н уртаклаша («... сокланып шәһәр буйлап йөрдем... Арча кырында атна буе бәйрәм булды... Болак күле, андагы көймәләр... Казансудагы Адмиралтейство бинасы... Күкерт заводы. Кремль, Болактагы пристань... Уң якта Казансуның бормалы ермаклары, аннан ерак түгел тау башындагы куе агачлар арасыннан Елантау монастыреның чиркәү манаралары күренә; монастырь аръягында Казан манзарасы ачыла. Иң алда ак кремль диварларының бойницалары; кремль тирәсендә төрле корылмалар, өйләр башлана...»).

Әсәр.: Полн. собр. соч.: В 3 т. М.–Л., 1938–52.

*Әд.:* Знаменитые люди о Казанском крае. К., 1990.

*Б.А.Канеев.*

**РАДИ́ЩЕВ РАЙОНЫ́**, *Ульянов өлкәсенең* көньягында урнашкан. Мәйданы — 1636 *км*$^2$. Үзәге — шәһәр тибындагы Радищево посёлогы (элек Дворянская Терешка; Ульянов шәһәреннән 238 *км* көньяктарак). Халкы — 13109 кеше (2013), татарлар — 1506 кеше (2010). Алар тупланып — район үзәгендә (1539 кеше), сирәгрәк Богдановка, Югары Маза, Калиновка, Кубра, Яңа Дмитриевка, Ореховка авылларында, Октябрьский посёлогында һ.б. торак пунктларда яшиләр. Р.р. территориясе Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы, 16–17 йөзләрдә нугай татарлары, калмыклар, кыргыз-кайсаклар (казакълар) йогынтысындагы зонага керә. Утрак халык, ш.и. татарлар, 17–18 йөзләрдә Сембер, Сызрань–Пенза һ.б. чик буе киртәләре төзелгәннән соң килеп урнаша. 1722 елда район терр-ясеннән агучы Терешка елгасы тирәсендәге җирләрне, башка йомышлы кешеләр б-н бергә, татар морзалары да ала. Хәзерге вакытта (2002 дән) Р.р.нда татар милли-мәдәни автономиясе эшли. Татар теле һәм мәдәнияте көннәре, Сабан туе үткәрелә. Бог-



В.В. Радлов.

дановка авылында «Дуслык» хатын-кызлар фольклор төркеме (1930 дан), шәһәр тибындагы Радищево посёлогында мәчет (2007 дән) эшли. Р.р.нда җәмәгать эшлеклесе Н.Ф.Габдрәшитова, хокук фән. д-ры В.А.Сәфәров туган.

**РА́ДЛОВ** (Radloff) Василий Васильевич (Фридрих Вильгельм) (5.1.1837, Берлин — 12.5.1918, Петроград), шәркыятьче галим, төрки телләр белгече, тел галиме, этнограф, археолог, тәрҗемәче, Петербург ФА академигы (1884). Берлин ун-тын тәмамлый (1858). 1858 елдан Россиядә. 1859–71 елларда Барнаул шәһәрендә яши, Алтай, Себер, Казакъстан һәм Урта Азия буйлап экспедицияләрдә йөри; төрки халыкларның телләре, фольклоры, этнографиясе, археологиясе буенча материал туплый. 1871 дән Казанда: Казан уку-укыту округының татар, башкорт, казакъ мәктәпләре инспекторы (1872 дән). 1884 тән С.-Петербургта: Петербург ФАнең Азия (1885–90), антропология һәм этнография (1894–1918) музейлары директоры. Урта һәм Көнчыгыш Азияне өйрәнү буенча Рус ком-тын оештыруны башлап йөрүче һәм рәисе (1903–18). 1891 дә Петербург ФАнең Монголиягә Орхон экспедициясе б-н җитәкчелек итә, 1898 дә Үзәк Азиягә Турфан экспедициясен оештыра, аның башында танылган археолог һәм этнограф Д.А.Клеменц тора. Беренчеләрдән булып борынгы төрки *Орхон-Енисей ташъязма ядкәрләрен* укып чыга, борынгы уйгыр ядкәрләрен өйрәнә һәм бастырып чыгара башлый. Р. — төрки телләрне чагыштырма-тарихи өйрәнүгә нигез салучыларның берсе («Төньяк төрки телләрнең чагыштырма грамматикасы» — «Сравнительная грамматика северных тюркских языков», Лейпциг, 1882; «Монголиянең борынгы төрки ташъязма ядкәрләре» — «Древнетюркские надписи Монголии», 1–2 чыг., СПб., 1894–95; «Төрки телләр морфологиясен тасвирлауга кереш фикерләр» — «Вводные мысли к описанию морфологии тюркских языков», СПб., 1911). Алтай һәм Көнбатыш Себер төрки халыкларына караган төрле лингвистик, фольклор, этнографик материал туплый һәм бастыра («Төрки кабиләләрнең халык әдәбияты үрнәкләре» — «Образцы народной литературы тюркских племён», 1–10 кис., СПб., 1866–1907), «Төрки телләр сүзлеге тәҗрибәсе» («Опыт словаря тюркских наречий», 1–4 т., М., 1888–1911) дип аталган күптомлы хезмәтен бастырып чыгара. Гомуми һәм төрки тел белеменә, төрки телләр этногенезына, классификациясенә, тарихи диалектологиясенә, төрки текстология, фольклористика, этнография, археологиягә багышланган фундаменталь хезмәтләр авторы.

Х е з м.: О языке куманов. СПб., 1884; Памятники уйгурского письма. Л., 1928.

*Әд.:* Тюркологический сборник: Памяти В.В.Радлова посвящается. М., 1972; К о н о н о в А.Н. История изучения тюркских языков в России: Дооктябрьский период. Л., 1982; Р е ш е т о в А.М. Академик В.В.Радлов: востоковед и музеевед // Радловские чтения — 2002: Материалы годичной науч. сессии. СПб., 2002; З а к и р о в а Л.Н. Лингвистическая деятельность В.В.Радлова в 1871–1884 гг.: Автореф. дис... К., 2012; М а т в е е в а П.А., Р е з в а н Е.А. «Камень на дороге времени» к 175-летию В.В.Радлова // Урало-алтайские исследования. 2012. № 1.

**«РА́ДОНЬ»**, көзге арыш сорты. 1998 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында М.Л.Пономарёва, С.И.Пономарёв һәм Р.Ә.Әсретдинова тарафыннан «Новозыбковская 150», «Саратовская 5», «Радзима» сортлары катнашында җирле селекциянең иң яхшы сорт үрнәкләре б-н гибридларны юнәлешле серкәләндерү алымы һәм катлаулы гибрид популяциясеннән даими сайлап алу юлы б-н чыгарыла. Диплоид форма. Башагы озынча-эллиптик формада, уртача озынлык һәм тыгызлыкта, соргылт-сары төстә. Кылчыклары уртача озынлыкта, ярым таралучан, тыгыз, сары. Башак тәңкәсе уртача озынлыкта, ланцетсыман, бик очлы. Бөртеге эре, соргылт-сары, ярымачык, 1000 бөртекнең авырлыгы 32–38 *г*. Сортның морфологик үзенчәлекләре: сары куныклы куе яшел яфраклы, бөртекчәләре төкле, тирән бураналы. Уртача өлгерешле; вегетация чоры 319–340 көн. Биеклеге 106–122 *см*, сабагы нык, сөрлегүгә бирешми. Салкынга чыдам; икмәк пешерү сыйфатлары яхшы. Сынаулар нәтиҗәсе буенча 2001 дән «Р.» дәүләт сортлар реестрына кертелгән, Урта Идел буе (ТР, Пенза өлкәсе), Идел-Нократ һәм Урал төбәкләрендә чәчүгә рөхсәт ителә.

**РА́ДЦИГ** Юрий Антонович (6.9.1900 — 1.8.1976, Казан), төзелеш механикасы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1959), проф. (1959), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1970). Казан ун-тын (1925), Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тын (1935) тәмамлый. 1918–30 елларда Казан мәктәпләрендә, пед. техникумында, РСФСР Мәгариф халык комис-тының Баш сәяси мәгариф ком-ты курсларында укыта, Казан шәһәр астрономия обсерваториясендә эшли. 1930–32 дә Казан энергетика ин-тында. 1932–76 да Казан авиация ин-тының материаллар каршылыгы каф. мөдире. Хезмәтләре оптималь конструкцияләр проектлаштыруга карый. Р. махсус матем. аппарат — көзгедәй (модуляр) функцияләр теориясен эшли, статик билгеләнми торган ферма һәм балкаларны исәпләү алымнарын тәкъдим итә. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Решения алгебраических уравнений методами многомерной геометрии // Тр. Казан. авиац. ин-та. 1949. Вып. 23; Основные положения теории зеркальных функций // Тр. Казан. авиац. ин-та. 1958. Вып. 33–34; К вопросу о построении практических методов расчёта статически неопределимых балок наименьшего объёма // Тр. Казан. авиац. ин-та. 1963. Вып. 77; Статически неопределимые фермы наименьшего веса. К., 1969.

**РА́ДЦИГ** Юрий Юрьевич (12.11.1936, Казан — 16.12.2010, Бөек Новгород ш.), радиоэлектроника өлкәсе галиме, югары белем бирүне оештыручы, техник фән. д-ры (1972), проф. (1973), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1999). 1959 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, радиоидарә каф. мөдире (1971–77). 1977 дән Новгород политехник ин-тында (хәзер Новгород ун-ты), ректор (1977–82), радиотехниканың теоретик нигезләре каф. мөдире (1977–93), теоретик һәм махсус физика каф. профессоры (1993 тән). Симметрик тасмасыман сызыклар ярдәмендә күп ноктадан ярсытыла торган үтә югары ешлыклы кәкресызыклы ярыклы антенналар буенча фәнни юнәлешкә нигез сала. Хезмәтләре электродинамика өлкәсенә, антенналар синтезына һәм аларны автомат проектлаштыруга карый. Р.ның фәнни-тикшеренү нәтиҗәләре оборона техникасының төрле системаларында куллану таба.

Х е з м.: О решении задач реализации амплитудно-фазового распределения поля в криволинейных щелевых излучателях // Вопр. радиоэлектроники. 1969. Вып. 12; Исследование щелевых антенн с покрытием. Новгород, 1980 (автордаш); Регуляризация интегральных уравнений щелевых и вибраторных антенн // Докл. РАН. 1995. Т. 344, № 4 (автордаш).

**РАЁ́ВКА** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 32 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 19 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 275 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Казиле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Питрәч, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән Питрәч р-нында. Халык саны: 1859 да — 81, 1897 дә — 128, 1908 дә — 163, 1920 дә — 201, 1926 да — 237, 1938 дә — 249, 1949 да — 334, 1958 дә — 203, 1970 тә — 178, 1979 да — 121, 1989 да — 66, 2002 дә — 28 кеше.

**РАЗБЕ́ЖКИНА** Марина Александровна (17.7.1948, Казан), киносценарист, кинорежиссёр. 1971 елда Казан ун-тының филол. ф-тын тәмамлаганнан соң, «Вечерняя Казань» г-тасында мәдәният бүлеге үзхәбәрчесе булып эшли; мәкаләләре «Ленинец» һәм «Комсомолец Татарии» г-таларында басыла. Казан кинохроника студиясенең кинопериодика бүлеге администраторы (1974 тән), сценарийлар авторы (1985 тән), өлкән мөхәррире (1986 дан). Р. сценарийлары буенча «Ялкынланып яныгыз» («Взвейтесь кострами», 1985; Алма-Ата шәһәрендә узган 15 нче бөтенсоюз кино фестивале призы), «Ә сезнең ишегалдында?» («А у вас во дворе?», 1987; СССР Эчке эшләр министрлыгы премиясе, Лос-Анджелес шәһәрендә узган кино фестивале дипломы; Мангейм, Мюнхен, Мәскәүдә узган кино фестивальләрендә күрсәтелә), «Бу аң-

лап булмый торган Галимҗанов» («Этот непонятный Галимзянов», 1988), «Мин инанам» («Я верую», 1989) фильмнары, «Зур театр» («Большой театр», 2000), «Рус терроры хроникалары» («Хроники русского террора», 2000) телевизион документаль сериаллары төшерелә. 1989 да Казан кинохроника студиясендә «Заман» («Время») тәҗрибә иҗат остаханәсе оештыру тәкъдиме б-н чыга; режиссёрлык эшчәнлеген башлап җибәрә, 1989–2005 тә үзе язган сценарийлар буенча 27 документаль фильм төшерә, алар арасында халыкара танылу алган «Успение», «Сораулар буенча концерт» («Концерт по заявкам»), «Юл азагы» («Конец пути») фильмнары (барысы да — 1991; Мәскәү, Фрейбург, Амстердамда узган халыкара кино фестивальләре дипломнары) бар. 1992–98 дә Казан ун-тында визуаль культура тарихы һәм теориясе буенча лекцияләр укый, бер үк вакытта РФ Госкиносының «Замандаш» («Современник») киностудиясендә эшли. 1997 дән Мәскәүдә яши һәм эшли. 1997–2000 дә «Мәскәү турында йөз фильм» («Сто фильмов о Москве») проекты кысаларында 4 фильм төшерә, алар арасында «Сабан туе» («Сабантуй»), «Славян биюләре» («Славянские танцы»), «Җир асты» («Подземка») фильмнары да бар; 2001 дә «Культура» телевизион каналы өчен «Геннадий Айги», «Сугыш һәм тынычлык. Өзекләр» («Война и мир. Фрагменты») фильмнарын төшерә. 2003–04 тә — Н.Нестерова ун-тында (Мәскәү), 2004–05 тә «Интерньюс» мәктәбенең кино һәм телевидение ф-тында укыта. 2004 тә үзен уен киносы режиссёры буларак сынап карый; «Урак өсте» («Время жатвы») фильмы 10 бүләккә, ш.и. Россия киносының «Европага тәрәзә» («Окно в Европу»; Выборг ш., 2004) 12 нче кинофорумында Гран-прига, Триест шәһәрендә (Италия, 2004) узган халыкара кинофестивальдә Гран-прига, Онфлёр шәһәрендә (Франция, 2005) узган халыкара кино фестивалендә иң яхшы дебют өчен призга лаек була.

*Е.П.Алексеева.*

**РАЗГИЛЬДИ́ЕВ** Бәшир Таһир улы (15.9.1942, Сталинград өлкәсенең Ленин р-ны Маляевка а.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1995). СССР Эчке эшләр министрлыгының Саратов юридик ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1998–2007 елларда Идел буе төбәк юридик ин-ты (Саратов ш.) директоры. Бер үк вакытта, 1998 дән, Саратов хокук академиясе җинаять эшләре һәм җинаять-башкару хокукы каф. мөдире. Хезмәтләре җинаять эшләре хокукына, җинаятькә нисбәтлелек, җинаятьчелеккә каршы көрәш мәсьәләләренә карый. Җинаять эшләре хокукы, гражданлык хокукы, процессуаль хокук, криминология, криминалистика, дәүләт һәм хокук теориясе буенча уку ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Уголовно-правовые проблемы прикосновенности к преступлению. Саратов, 1981; Задачи уголовного права РФ и их реализация. Саратов, 1993; Уголовно-правовые отношения и реализация ими задач уголовного права. Саратов, 1995.

**РАЗЕНКО́В** Иван Петрович (26.11.1888, Сембер губ. Кадыковка а. — 14.11.1954, Мәскәү), физиолог, мед. фән. д-ры (1934), СССР МФА академигы (1944), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1940). Н.А.*Миславский* шәкерте. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1914), физиол. кафедрасында профессор стипендиаты итеп калдырыла. 1915 елдан Россия армиясендә, Томскида, Себернең башка шәһәр госпитальләрендә эшли, бер үк вакытта, 1920 дән, Томск ун-тында һәм Физкультура ин-тында укыта. 1923 тән И.П.Павлов лаб-ясендә (Петроград). 1924 тән Мәскәүдә: В.А.Обух исем. Һөнәри авырулар ин-тында физиол. лаб-ясе җитәкчесе, бер үк вакытта К.Либкнехт исем. Индустриаль-пед. һәм К.А.Тимирязев исем. Биол. ин-тларында каф. мөдире. 1929 дан СССР МФАнең Туклану ин-тында махсус физиол. бүлеге мөдире, проф. (1932). Бөтенсоюз эксперим. мед. ин-тының Мәскәү ф-лы директоры (1932–34), директор урынбасары (1935–36). Үзәк табибләр белемен күтәрү ин-тының кеше физиологиясе бүлеге җитәкчесе (1935–44), бер үк вакытта физиол. каф. мөдире (1936–40). Мәскәүнең 1 нче мед. ин-тында физиол. каф. мөдире (1939–51). 1944–50 дә СССР МФАнең Физиол. ин-ты директоры, бер үк вакытта, 1948–50 дә, СССР МФА вице-президенты, физиол. һәм патология лаб-ясе мөдире. 1950 елдан СССР МФАнең Туклану ин-тында фәнни консультант. Хезмәтләре вегетатив нерв системасы патологиясенә, югары нерв эшчәнлегенә, ашкайнату физиологиясенә карый. 3 монография авторы. Мәскәү физиологлар, биохимиклар һәм фармакологлар җәмгыяте (1930–51), Бөтенсоюз физиологлар җәмгыяте рәисе (1934–37). СССР ФАнең И.П.Павлов исем. бүләге лауреаты (1939); биеклек шартларында ашкайнату физиологиясен өйрәнүдәге хезмәтләре өчен СССР Дәүләт бүләге бирелә (1947). Ике Ленин ордены, И.П.Павлов алтын медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Условия и механизм вазомоторных свойств крови. М., 1927; Влияние высокой температуры на животный организм и организм человека. М.–Л., 1934; Новые данные по физиологии и патологии пищеварения. М., 1948; Руководство к практическим занятиям по физиологии. М., 1948.

*Әд.:* О х н я н с к а я Л.Г., В и ш н я к о в а И.Н. Иван Петрович Разенков. 1888–1954. М., 1991.

**РАЗЖИ́ВИН** Дмитрий Александрович (12.11.1976, Чаллы ш.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007), техник фән. канд. (2005). Казан ун-тын тәмамлый (1998). ТатНИПИнефтьтә эшли, чыганакларның даими эшләүче модельләрен төзү лаб-ясе мөдире (2006 дан). Хезмәтләре нефть чыганакларын эшкәртүгә карый. Дәүләт бүләге автоматлаштырылган проектлау технологияләре нигезендә нефть чыганакларын эшкәртү алымнарын булдыруда һәм сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

Х е з м.: Использование геолого-технологических моделей при создании проектов разработки нефтяных месторождений // Георесурсы. 2002. № 3; Выделение геологических тел по трёхмерной модели разработки для проектирования МУН // Нефтяное хоз-во. 2004. № 10.

**РА́ЗИН** Степан Тимофеевич (1630 тирәсе, Зимовейская-Дон станицасы, 6.6.1671, Мәскәү), Дон казагы, 1670–71 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышы* җитәкчесе. 1662–63 тә Дон атаманы, Кырым татарлары һәм төрекләр б-н сугыша. 1667–69 да ярлы казак отрядлары һәм качкын крәстияннәр б-н Идел буенда һәм Каспий диңгезе буендагы шәһәрләрдә юлбасарлыкта йөри. 1670 нең язында Идел буена юнәлә. Р.ның хөкүмәткә каршы чыгышы казакләр, алпавыт крәстияннәре, бистә кешеләреннән торган көчле хәрәкәткә әверелә. Хәрәкәттә Идел буе халыклары, ш.и. татарлар да катнаша. 1670 нең май–август айларында разинчылар Царицын, Әстерхан, Саратов, Самараны алалар; сентябрьдә Сембер шәһәре камала. Х.*Карачурин*, *Иштирәк абыз* һ.б. баш күтәрүчеләр татарларны хәрәкәткә кушылырга өнди. Карачурин Р.га, татарларның ярдәменә ышандырып, Казанга барырга тәкъдим итә. Татарларның бер өлеше фетнәләрдә, Саранск, Керенск, Козьмодемьянск шәһәрләрен алуда, Арзамас һәм Сембер янындагы сугышларда катнаша. 1670 нең октябрендә Р. Сембер янында җиңелә. 1671 нең апрелендә бай казаклар, Р.ны кулга алып, патша хөкүмәтенә тотып бирәләр. Мәскәүдә җәзалап үтерелә.

*Әд.:* С т е п а н о в И.В. Крестьянская война в России в 1670–1671 гг.: Восстание Степана Разина: В 2 т. Л., 1966–72.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**РА́ЗОВ** Мирһади Мирзаян улы (22.10.1960, Актаныш р-ны Аеш а.), шагыйрь, тележурналист. Казан ун-тын тәмамлый (1991). 1979 дан КамАЗда эшли. 1989–93 тә «Нур» г-тасында хәбәрче, әдәбият, мәдәният һәм тел бүлеге мөдире (Чаллы ш.). 1995 тән Халык депутатларының шәһәр советы һәм Чаллы шәһәре мэриясенең телерадиотапшырулар редакциясендә (2006 дан — «Чаллы-ТВ» дәүләт телерадиокомпаниясе) әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси программалар мөхәррире. «Кыйбла», «Әйлән-бәйлән», «Чаллы утлары», «Шигъри дулкын» телевизион тапшыруларын алып бара. Разовның шигырьләре «Идел» альманахында (1978), «Беренче карлыгачлар» (1988) күмәк җыентыгында басыла. «Моңлы биләү» (1993) җыентыгы авторы. Разовның шигырьләренә И.Закиров, В.Әхмәтшин, А.Якшимбәтов, З.Хәйретдинов, В.Агапов һ.б. тарафыннан популяр җырлар языла.

**РА́ЗУМОВ** Александр Иванович (5.1.1897, Самара губ., Мусорка а. — 31.8.1987, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1958), проф. (1960), ТАССРның һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1965, 1972). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1922), шунда ук эшли (1919 елдан, студент вакыттан ук укыта башлый). 1930 дан Казан химия-технол. ин-тында, директор урынбасары (1932–35), органик химия каф. мөдире (1962–81). Хезмәтләре фосфорорганик кушылмалар химиясенә карый. Р. фосфон, фосфин һәм фосфинлы к-таларның кушылмаларын, фосфориллы гетероциклларны, өчвалентлы фосфор к-таларының тиоэфирларын тикшерә. Фосфориллы карбонил һәм чиксез кушылмалар химиясенә, өч- һәм бишвалентлы фосфор хлорангидридлары, биол. актив кушылмалар химияләренә, ш.у. Арбу-

зов реакциясе механизмын өйрәнүгә зур өлеш кертә. Серкә альдегидының симметрик булмаган фосфориллы ацетальләрен, пиридинның гидразин төркемле фосфориллы кушылмаларын табу юлларын күрсәтә. Илдә беренчеләрдән булып дару препаратларын синтетик фосфорорганик кушылмалар арасыннан эзләп табу мәсьәләсен хәл итә. Р. җитәкчелегендә дару препаратлары *армин*, нибуфин, фосфобензид эшләнә һәм мед. практикасына (офтальмология, хирургия, гинекология) кертелә. Уйлап табуга 100 гә якын авторлык таныклыгы бар. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сравнительная характеристика смешанного аллилового-изопропенилового эфира этилфосфиновой кислоты и его полимера // Фармакология и токсикология фосфорорганических соединений и других биологически активных веществ. К., 1969 (автордаш); Взаимодействие полных эфиров α-алкоксиэтилфосфоновых кислот с пятихлористым фосфором // Журн. общей химии. 1973. № 1 (автордаш).

*Әд.:* К а м а й Г.Х., К и р п и ч н и к о в П.А., Л и о р б е р Б.Г. Александр Иванович Разумов (к 70-летию со дня рождения) // Журн. общей химии. 1967. Т. 37, вып. 7; Профессора, доктора наук. Политехнический институт – КХТИ – КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

*В.Г.Абзалова.*

**РА́ЗУМОВ** Михаил Осипович (Архангцев Арон Иосифович) (1894, Чернигов губ. Глухов ш. – 30.10.1937, Мәскәү), партия эшлеклесе. 1899 елдан Донбасста. 1913 тә Петербургта төзүче, кадак з-дында эшче, сәяси стачка оештырганы өчен эштән куыла. РСДРП(б)ның Петроград ком-ты әгъзасы. 1914 тә Луганск шәһәренә күченеп китә. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында, 1915 тә, Россия армиясенә алына, авыр яралана. Окт. рев-циясендә катнаша (Петроград). 1919–20 дә Одесса Хәрби округының сәяси идарәсе башлыгы, Көньяк фронт частьләрендә Кызыл Армиянең сәяси идарәсе инспекторы. Соңрак Донбасста хакимият һәм партия эшендә. РКП(б)ның Рыбинск (1922–23), Орёл (1923–24) губерна ком-тлары, ВКП(б)ның Башкортстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре. 1927 дә Кытайга хәрби киңәшче итеп җибәрелә. 1928–33 тә – ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты, 1933–37 дә Көнчыгыш Себер крае ком-ты 1 нче секретаре. Репрессияләр чоры корбаны; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* С у б а е в Н. Разумов Михаил Осипович // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2; Центральный комитет КПСС, ВКП(б), РКП(б), РСДРП(б): Ист.-биогр. справ. М., 2005.

*Р.Х.Әхмәтҗанов.*

**«РАЗУМО́ВСКИЙ»**, Алексеев р-нындагы совхоз. 1965 елда Бутлеров исем. с-з җирлегендә оештырыла. Үзәк утары – Зур Тигәнәле авылы. А.х. файдалану җирләренең мәйданы 6575 *га*, шулардан сөрүлек җирләр – 6042 *га*. Эшләүчеләр саны 268 кеше. Төп юнәлешләре – бөртекле ашлык, сөт, ит җитештерү. 1991–95 елларда бер елга бөртекле ашлык – 8081 *т*, сөт – 2168 *т*, ит 276 *т* җитештерелә; бөртекле ашлыкның уртача уңышы 1 *га* дан 26,5 *ц* тәшкил итә, еллык савым уртача һәр сыердан – 3957 *кг*; җитештерүнең табышлылык дәрәҗәсе – 27%. Совхозның өч эшчесе ТАССРның атказ. механизаторы исеменә лаек була. 1996 да совхоз «Зур Тигәнәле» а.х. җитештерү кооперативы итеп үзгәртелә. Хуҗалык җитәкчеләре: М.Ә.*Сираев* (1965–68), Ф.Ш.Сабитов (1968–75), Җ.К.*Әхмәтҗанов* (1975–2000).

**РАЗУМО́ВСКИЙ** Василий Иванович (27.3.1857, Самара губ., Николаев өязе Ефимовка а. – 7.4.1935, Ессентуки ш.), хирург, медицина д-ры (1884), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1934). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1880), шунда ук, проф. Л.Л.Лёвшин җитәкчелегендәге госпиталь хирургиясе клиникасында эшли. 1883–84 елларда Хәрби мед. академиясендә (С.-Петербург). 1885–1909 да Казан ун-тында, 1891 дән госпиталь хирургиясе клиникасы җитәкчесе, ординар проф. (1894), мед. ф-ты деканы (1905–07); бер үк вакытта Александра хастаханәсендә хирургия бүлеге мөдире. 1889 да һәм 1891 дә Германия, Австрия, Франциядә фәнни командировкаларда була. Декан вазифасында беренче булып мед. ф-тына хатын-кызларны кабул итә башлый. 1904 тә Нобель ком-ты тарафыннан рус галимнәрен Нобель премиясенә тәкъдим итү өчен сайлана. 1909–12 дә Николай исем. ун-т (Саратов ш.) ректоры, бер үк вакытта факультет хирургиясе кафедрасында ординар проф., атказ. проф. (1911), 1920 дән пропедевтик клиникалы гомуми хирургия каф. мөдире. 1916 да Петроградта сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы иптәше (урынбасары) итеп раслана. 1917 дә Кавказ фронтының баш хирургы. Россиядәге өч югары уку йортының – Пермь травматология ин-ты (1917), Тифлис шәһәрендә Кавказ арты рус ун-ты (1918), Баку ун-тының (1919) оештыручысы була. 1930 елдан Ессентуки шәһәр сәламәтлек саклау бүлеге консультанты һәм курортлар хезмәтенең фәнни бүлеге рәисе. Хезмәтләре нейрохирургиягә, корсак куышлыгы хирургиясенә, урологиягә, сөяк пластикасына, хиругия фәнен укытуга, мед. тарихына карый. 1, 2 һәм 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 һәм 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә. Хезмәт Герое (1923).

Х е з м.: О причинах смерти после хирургических операций и повреждений. К., 1887; Воспалительные процессы на шее. СПб., 1902; Повреждения и заболевания щитовидной железы. СПб., 1903; Раковая болезнь и борьба с ней. Саратов–М., 1926; Современная хирургическая операция. Саратов–М., 1926.

*Әд.:* М и р с к и й М.Б. В.И.Разумовский как историк хирургии (к 125-летию со дня рождения) // Советское здравоохранение. 1983. № 5.

*В.Ф.Богоявленский.*

**РАЙ́ФА**, к. *Местечко Раифа.*

**РАЙ́ФА** посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сумка елгасы буенда. Даими яшәүчеләр юк. 20 йөз башында Раифа юлындагы хутор булarak нигез салына. Оештырылган көннән Казан губернасының Казан өязе Ильинка волостенда, 1920 елдан ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән – Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан – Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1920 дә – 63, 1926 да – 106, 1938 дә – 129, 1949 да – 70, 1958 дә – 97, 1970 тә – 49, 1979 да – 25, 1989 да – 4, 2002 дә – 3 кеше (татарлар).

**РАЙ́ФА БОГОРО́ДИЦА ПУСТЫНЕ́**, к. *Богородица пустыне.*

**РАЙ́ФА КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама аръягында. Идел елгасының биек террасасында урнашкан, Яшел Үзән р-ны Раифа посёлогы янында. Сумка елгасы бассейнына карый. Идел-Кама саклаулыгының саклаулы зонасына керә. Су өслегенең мәйданы 33,2 *га*. Су күләме якынча 2300 мең $м^3$. Озынлыгы 1465 *м*, иң зур киңлеге 320 *м*. Уртача тирәнлеге 7,2 *м*, иң зур тирәнлеге 19,8 *м*. Формасы озынча, бормалы. Ярлары сөзәк, төньяк, көньяк һәм көнбатышта катнаш урман б-н капланган. Р.к. карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә Сумка елгасы үзәнендә барлыкка килгән. Элек баш-башларында 2 плёсы булган, көньяк-көнбатыштан төньяк-көнчыгышка сузылган зур сулык (Олы Раифа күле)



Раифа күле.

була. 18–19 йөзләрдә комлы-балчыксыл утырмалар туплану барышында Олы Раифа күле әкренләп 2 сулыкка бүленә: Сумка күле (соңрак – Монастырь, хәзер Р.к.) һәм *Аккүл*. Р.к. агымлы – аның аша Сумка елгасы ага, аңа Сәр-Болак елгасы коя. Су алмашыныш ешлыгы – елына якынча 9 әйләнеш. Сумка елгасы б-н килгән йөзмә матдәләрнең туплануы нәтиҗәсендә, күлнең төньяк өлешендә сай сулыкка тоташучы комлы пляж барлыкка килгән, шул сәбәпле соңгы 100 елда күл 700 *м* га кыскара. Мелиоратив чаралар нәтиҗәсендә (сөзәкләрдә урман утырту, буалар төзү), Сопа һәм Сумка елгалары бассейнында Р.к.нең ләмләнүе шактый кими. Туенуы – катнаш, җир өсте һәм җир асты сулары исәбенә. Р.к.нең язгы су күтәрелеше Сумка елгасындагы ташу вакыты б-н бәйле. Ташу вакытында су бик болганчык (үтә күренмәлелеге 15 *см*), җәй ахырында үтә күренмәлелек 173 *см* га җитә. Суының минеральләшүе түбән, язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Суы гидрокарбонат-хлорид-магнийлы типта. Суының иң аз вакытында төсе саргылт-яшелдән ташу чорында көрәнгә кадәр үзгәрә. Җәйге чорда Р.к.дә суның темп-ра стратификациясе күзәтелә: өске катламы 19–27 °С, 4–6 *м* тирәнлектә 14–16 °С, 8–17 *м* тирәнлектә 4–6 °С ка кадәр җылына; кышын суның бар-

лык катламында темп-ра 0,8 дән 3,3 °С ка кадәр була. Күл, гадәттә, ноябрь уртасында боз б-н каплана, апрельнең 3 нче ункөнлегендә боздан арына. Чуртан, өсләч, чабак, алтын табан балык, карабалык, алабуга һ.б. балыклар яши. Р.к. буенда *Раифа Богородица пустыне* урнашкан, күлнең хәзерге исеме шуннан алынган. Ел саен Крещение Господне (19 гыйнвар) православие бәйрәмендә күлдә боз скульптуралары комплексы корыла.

*Әд.:* Унковская Б.Н., Мингазова Н.М., Павлова Л.Р. Гидрологическая и гидрохимическая характеристика водоёмов Раифы // Тр. Волжско-Камского гос. природного заповедника. 2002. Вып. 5; Тайсин А.С. Озёра Приказанского района, их современные природные и антропогенные изменения. К., 2006.

**«РАЙФА МОНАСТЫРЕ́» ЭШЕ́**, 1930 елда СССР ОГПУсының Татарстан бүлеге тарафыннан оештырылган гаепләү эше. Бер төркем кеше «1918 елда Раифа монастырендә кызылармиячеләрне явызларча үтерүдә» (к. *«Раифа» эше*), крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү чорында «авыл хуҗалыгын үзгәртеп кору өлкәсендәге башлангычларга аяк чалу максатыннан, халыкның дини инануларын файдаланып... хөкүмәт күргән чараларга каршы агитация алып баруда», кулаклар б-н бәйләнештә торуда, ш.у. чиркәү җиһаз-мөлкәтен хөкүмәткә тапшыру барышында (1922, 1928) кайберләрен яшереп калдыруда гаепләнә. Эш буенча 43 кеше, ш.и. 33 дин әһеле (ябылган Раифа монастыре монахлары, таркатылган Казан Богородица, Фёдор, Зөя Иоанн-Предтеча хатын-кызлар монастырьлары монахинялары) һәм якын-тирә авыллардан 10 крәстиян җавапка тартыла. Мәхкәмә процессы 1930 ның 23 гыйнварыннан 20 февраленә кадәр бара. СССР ОГПУсының Татарстан бүлеге «өчлеге» тарафыннан 1930 ның 20 февралендә кабул ителгән карар нигезендә (РСФСР Җинаять кодексының 58 нче маддәсе, 10, 11 нче пунктлар) 8 кеше: иеромонахлар Иосиф (Гаврилов), Сергий (Гуськов), Варлаам (Похилюк), Иов (Протопопов), Антоний (Чирков), послушник Пётр (Тупицын), крәстияннәр С.Абрамов, В.Гаврилов — атарга; 15 кеше — 5 елга концлагерьга ябылуга; 19 кеше Төньяк крайга сөрелүгә хөкем ителә. ТАССР Прокуратурасының 1990 елгы карары б-н гаепләнүчеләрнең барысы да аклана.

**РАЙФА УРМАНЫ́**, урман массивы, уникаль табигать истәлеге, Яшел Үзән р-ны терр-ясендә, Идел-Кама дәүләт табигать биосфера саклаулыгы Раифа участогының нигезен тәшкил итә. Мәйданы 5921,2 *га*. Идел елгасы үзәненең сульяк сөзәклегенең урта дүртенчел чор тугай өсте террасасында урнашкан. Борынгы аллювиаль көпшәк утырмаларда барлыкка килгән казансыман түбәнлекне били. Туфрак капламының төп фонын җиңелчә бөртекле (комлыдан комсыл балчыкка кадәр) көлсу һәм кәсле-көлсу туфраклар тәшкил итә. Мәйданының якынча 50% ында карт агачлар үсә, 407 *га* ны Көнчыгыш Европадагы иң карт утыртмалар (200 ел һәм күбрәк) били. 713 *га* да урман культуралары, ш.и. экзотик агач һәм куакларның 40 тан артык төре үсә. Урманнар яхшы сакланган булулары, бергәлекләрнең югары биотөрлелеге б-н характерлана. Р.у. терр-ясендә урман ассоциацияләренең 36 тибы билгеләнә. Югары продукция бирә торган утыртмалар (900 $м^3/га$ га кадәр) тәшкил итүче мүкле һәм чыршы катнаш наратлыклар өстенлек итә. Нарат, чыршы һәм юкәдән торучы ылыслы-киң яфраклы урманнар; имән, өрәңге, карама катнаш киң яфраклы юкә урманнары, тоташ кисүгә дучар булган урыннарда үскән каенлыклар шактый зур мәйданнарны били. Мүкле-лишайниклы наратлыклар, усаклыклар, кара зирекле тугай урманнары, торф мүкле һәм каен-күрәнле сазлыклар аз таралган. Умырткалыларның — 210, умырткасыз хайваннарның — якынча 3000, үсемлекләрнең — 1500, гөмбәләрнең 754 төре билгеләнгән.



Раифа урманы.
200 еллык мүк җиләкле-мүкле наратлык.

17 йөздән 20 йөз башына кадәр Раифа урман дачасы (1148 *га*) Раифа Богородица ирләр монастырена (Р.у.ның исеме шуннан) карый. 1919 да урман дачасы (Паратский һәм Казан урман дачалары өлеше б-н берәттән) Казан ун-ты урман ф-тының яңа барлыкка килгән Раифа укыту-тәҗрибә урманчылыгы (2611 *га*) составына керә. Берничә тапкыр үзгәртелеп оештырылганнан соң, 1927 дә урманчылык мәйданы 1259 *га* га киңәя. 1960 тан — *Идел-Кама саклаулыгының* Раифа участогы; 2001 дә Яшел Үзән урман хуҗалыгының Кызыл Октябрь урманчылыгы җирләре исәбенә 2057 *га* га арта. 2005 елдан Р.у. ЮНЕСКО МАБ биосфера резерваты зур Идел-Кама саклаулы үзәгендәге ике участокның берсе булып тора.

Казан геоботаника мәктәбе, Идел буе югары урман мәктәбенең формалашуында һәм тарихи үсешендә, төрле профильдәге белгеч-экологларны әзерләүдә Р.у. билгеле бер роль уйный. С.И.Коржинский, А.Е. һәм Б.А.Арбузовлар, И.В.Тюрин, П.Н.Крылов, А.Я.Гордягин, Н.А.Ливанов, А.П.Ильинский, А.П.Тольский, Л.И.Яшнов, В.А.Попов, Д.И.Морохин һ.б. зур галимнәрнең исемнәре аның б-н бәйле.

*Әд.:* Порфирьев В.С. Растительность Раифы // Тр. Волжско-Камского гос. заповедника. 1968. Вып. 1. *В.Б.Иванов.*

**РАЙФА ШӘҺИДЛӘРЕ́**, 1930 елда большевиклар тарафыннан атып үтерелгән *Раифа Богородица пустыне* руханилары. Пустынь 1928 дә ябылганнан соң, якын-тирә авылларда яшәүче крәстияннәр, элекке монахлар һәм Раифа халкы б-н бергә христиан җәмгыятен торгызалар һәм монастырь храмнарының берсендә дини йолалар үткәрүне дәвам иттерәләр. Большевиклар, Раифа монастырендә кызылармиячеләрне үтерүдә, советка каршы агитация алып баруда һәм чиркәү хәзинәләрен яшерүдә гаепләп (к. *«Раифа монастыре» эше, «Раифа» эше*), 1930 ның 23 гыйнварында монастырьда һәм күрше авылларда яшәүче дини җәмгыять активистларын кулга алалар. 27 гыйнварда, литургия уздырылуга, храмда булган бар халык кулга алына. 1930 елның февралендә СССР ОГПУсының Татарстан бүлеге «өчлеге» иеромонахлар Иосиф (Гаврилов, 1868 дә туган), Сергий (Гуськов, 1875 тә туган), Варлаам (Похилюк, 1870 тә туган), Антоний (Чирков, 1868 дә туган), Иовны (Протопопов, 1880 дә туган) һәм послушник Пётрны (Тупицын, 1906 да туган) атарга хөкем итә (карар 7 апрельдә җиренә җиткерелә; Сергий 1930 ның 10 августында җәзалана). 2 авыл кешесе: Василий Гаврилов һәм Степан Абрамов та шундый ук җәзага тартылалар; башка кулга алынганнар сөргенгә (15 кеше — концлагерьга) озатыла. Р.ш., Казан епархиясенең җирле искә алынучы изгеләре буларак, 1997 елның 6 апрелендә канунлаштырылалар. Алар 27 гыйнварда искә алына.

*Әд.:* Новые преподобномученики Раифские. М., 1997.

**«РАЙФА» ЭШЕ**, 1925 елда СССР ОГПУсының Татарстан бүлеге тарафыннан оештырылган гаепләү эше. Бер төркем кеше 1918 елның 15 июнендә Раифа монастыре терр-ясендә җиде кызылармиячене явызларча үтерүдә һәм мәетләрен яндыруда гаепләнә (чынлыкта кызылармиячеләрне, погромчылар һәм мародёрлар дип белеп, якын-тирә авыл крәстияннәре юк итә). Эш буенча 23 кеше: И.И.Агеев, М.И.Алексеева, А.М.Архипов, И.Барсков, П.Н.Булихин, И.П.Власов, В.Г.Гаврилов, Т.Голышев, Е.П.Ермаков, И.Д.Илюшин, П.А.Калинкин, Г.М.Макаров, Е.М.Макаров, Н.И.Макаров, А.И.Нестеров, И.А.Нестеров, Я.А.Нестеров, М.Е.Новожилов, М.П.Ретин, Г.Ф.Сергеев, С.Ф.Федин, С.Федин, С.Янакин җавапка тартыла. Эш ТАССР Баш мәхкәмәсенең күчмә сессиясе тарафыннан 1925 нең 31 август – 4 сентябрендә Раифа монастыре терр-ясендә карала (РСФСР Җинаять кодексының 60, 64 нче маддәләре). Унбер кеше төрле елларга: М.И.Алексеева, И.Барсков, Н.И.Макаров, А.И.Нестеров — 2 елга (амнистия буенча азат ителәләр), П.Н.Булихин, Е.П.Ермаков — 4 елга (амнистия буенча 1 елга калдырыла), С.Янакин — 6 елга (2 елга калдырыла), В.Г.Гаврилов — 10 елга (4 елга калдырыла), Г.Ф.Сергеев — 5 елга (1,5 елга калдырыла), С.Ф.Федин — 2 елга, Т.Голышев 5 елга төрмәгә ябылуга хөкем ителә. РСФСР Югары мәхкәмәсенең җинаять кассацияләре коллегиясе, 1925 елның 14 декабрь карары б-н, гаепләнүчеләрнең барысын да аклый, эш туктатыла. Ш.у.к. *«Раифа монастыре» эше.*

**РАЙГРА́С** (ингл. rue grass — арыш үләне), кыяклылар семьялыгыннан үләнчел терлек азыгы үсемлеге, ике ыругка карый: Arrhenatherum (озын Р.) һәм Lolium (көтүлек Р.ы,

күп тапкыр чабыла торган Р.). Озын Р. (A. elatius) — күпьеллык сирәк куаклыклы, кыяклы, язгы типтагы, 80–160 *см* лы үсемлек. Яфракларының өсте кытыршы. Чәчәк оешмасы себеркәчле, ботаклары ике чәчәкле (түбәнге чәчәге җитлекмәгән). Тамыр системасы туфракка тирән китә, бу корылыкка чыдамлыгын арттыра. Салкынга чыдамлыгы югары түгел. Кыргый биек Р. бөтен Европада, Урта Азиянең таулы-урманлы болыннарында очрый; уңдырышлы киптерелгән һәм торфлы туфракларда үсә; су басуны начар кичерә. 100 *кг* печәндә 46,7 азык берәмлеге, 3,4 *кг* үзләштерелә торган протеин бар. Яшел массасының тәме ачы һәм башка кыяклы һәм кузаклы үләннәр б-н генә ашатыла. Көтүлек Р.ы, яисә инглиз Р.ы (L. perenne) — күпьеллык сирәк куаклыклы, көзге типтагы 15–20 *см* дан 60–70 *см* га кадәр биеклектәге кыяклы үсемлек. Сабаклары күп яфраклы. Яфраклары иелмәгән, түбәнге ягы ялтыравыклы. Чәчәк оешмасы — башак. Кыргый төре болыннарда, чүпле урыннарда, кыр межаларында очрый. Иң яхшы көтүлек һәм газон үсемлеге. Бер кат терлекләргә ашатканнан соң яхшы үсә. Барлык терлекләр дә ашый. Күп чабыла торган Р. яисә итальян Р.ы (L. multiflorum) бер яисә икееллык күп яфраклы, 20–60 *см* озынлыктагы кыяклы үсемлек. РФдә аның берьеллык төре — вестервольд Р.ы (терлек азыгы массасын күп бирүче үсемлек) яшел терлек азыгы өчен һәм печән буларак солы һәм вика катнашында кулланыла. Яшел массасын барлык терлекләр дә ашый. 100 *кг* печәндә 51 азык берәмлеге һәм 4 *кг* үзләштерелә торган протеин бар. РФ Дәүләт реестрында соңгы 10 елда Россиянең барлык төбәкләрендә 40 тан артык сорты чәчәргә рөхсәт ителгән, шуларның 18 сорты Россия селекциясенеке, ш.и. 7 се (Стрелец, Талан, Слизнец, Московский 74, Альпийский, Веймар, Карат) Урта Идел төбәгендә чәчәргә рөхсәт ителә.

*Әд.:* М а р к о в М.В. Злаки Татарской АССР. К., 1961; Б а к и н О.В., Р о г о в а Т.В., С и т н и к о в А.П. Сосудистые растения Татарстана. К., 2000. *О.Л.Шайтанов.*

**РАЙКО́ВО**, к. *Раевка.*

**РАЙЛА́Н** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 24 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Дим елгасы буенда. 2010 елда 52 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык, ат асрау. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Баулы волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1938 дә — 233, 1949 да — 216, 1958 дә — 121, 1970 тә — 150, 1979 да — 133, 1989 да — 93, 2002 дә — 72 кеше.

**РАЙО́Н** (франц. rayon — луч, радиус), авыл җирлегенең төп адм.-терр. берәмлеге, респ-ка, край, өлкә, автономияле округлар һәм зур шәһәрләрнең бер өлеше. ТАССРда беренче 8 район БҮБК Президиумының 1927 ел 14 февраль карары б-н гамәлдәге кантоннар бүленеше (к. *Кантон*) җирлегендә төзелә. Зөя кантоны Зөя, Тәмте, Кайбыч (1927 нең 1 августына кадәр — Ульянково) һәм Норлат (1927 нең 1 августына кадәр — Норлат-Ачасыр) р-ннарына бүленә. Лаеш кантоны да таркатыла, аның терр-ясендә Лаеш һәм Балык Бистәсе р-ннары (Лаеш кантонының районнар составына кермәгән өлеше Арча һәм Мамадыш р-ннарына бирелә) оештырыла. Арча кантонының көньяк-көнбатыш волостьларының бер өлешеннән — Казан авыл р-ны (1927 нең 1 августыннан — Воскресенский), Алабуга кантонының төньяк-көнчыгыш өлешеннән Әгерҗе р-ны төзелә. 1930 ның 10 августында БҮБК Президиумының ТАССРда яңа адм. бүленеш турындагы карары кабул ителә, бу карар буенча моңарчы булган кантон, волость һәм аерым районнарга бүленү тулысынча районнарга бүленеш б-н алмаштырыла. Булган 8 районга өстәмә 38 район: Аксубай, Актаныш, Акташ, Алабуга, Алексеев, Апас, Арча, Әлки, Әлмәт, Әтнә (1938 нең 25 мартыннан — Тукай), Баулы, Беренче Май, Биләр, Бондюг, Бөгелмә, Буа, Дөбъяз, Кама Тамагы, Красный Бор, Кукмара, Мамадыш, Минзәлә, Мөслим, Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат), Питрәч, Саба, Сарман, Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев), Тәкәнеш, Тәтеш, Тымытык (1931 нең 20 октябреннән — Азнакай), Түнтәр (1932 нең 2 мартыннан — Балтач), Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай), Чистай, Чүпрәле, Ширәмәт, Шөгер (1959 ның 12 октябреннән — Лениногорск), Яңа Чишмә р-ннары оештырыла. 1930 ел ахырына 46 район исәпләнә.

1931–35 елларда ТАССРда адм.-терр. бүленеш үзгәрә. БҮБК Президиумының 1931 ел 20 гыйнвар карары нигезендә Бондюг р-ны Алабуга р-ны составына кертелә, 1931 нең 20 октябрендә Зөя һәм Тәмте р-ннары таркатыла, алар урынына Югары Ослан р-ны оештырыла (бетерелгән р-ннардагы авылларның бер өлеше Апас, Норлат, Кама Тамагы р-ннарына бирелә), 1932 нең 1 гыйнварында Тәкәнеш р-ны таркатыла, аның бер өлеше Мамадыш һәм Кукмара р-ннарына кушыла. 1934 ел ахырына ТАССРда 43 район була.

Районнар бүлену б-н, 1935, 1938 һәм 1944 тә яңа районнар барлыкка килә, аларның иң күп чагы 1940 еллар ахырына туры килә.

БҮБК Президиумының 1935 ел 25 гыйнвар карары нигезендә тагын 17 район: Бондюг (Алабуга һәм Красный Бор р-ннарының бер өлешеннән), Будённый (1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы; Буа һәм Чүпрәле р-ннарыннан), Биектау (Арча, Дөбъяз, Питрәч, Казан авыл р-ннарыннан), Ворошилов (1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл; Минзәлә, Сарман, Чаллы р-ннарыннан), Зәй (Акташ, Сарман, Чаллы, Ширәмәт р-ннарыннан), Калинин (Акташ, Минзәлә, Мөслим р-ннарыннан), Кызыл Армия (Чистай р-ныннан), Кызыл Йолдыз (Мамадыш, Балык Бистәсе, Саба р-ннарыннан), Кызыл Юл (1956 ның 18 июленнән — Тукай; Арча, Әтнә, Балтач р-ннарыннан), Кузнечиха (Әлки, Спас р-ннарыннан), Яңа Писмән (1955 нең 18 августыннан — Лениногорск; Әлмәт, Бөгелмә, Шөгер р-ннарыннан), Тәкәнеш (Кукмара, Мамадыш, Саба р-ннарыннан), Тельман (Аксубай, Биләр, Октябрь р-ннарыннан), Тәмте (Апас, Югары Ослан, Кама Тамагы р-ннарыннан), Тымытык (Азнакай, Мөслим, Сарман р-ннарыннан), Теләче (Арча, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба р-ннарыннан), Ютазы (Азнакай, Баулы, Бөгелмә р-ннарыннан; 1958 нең 28 февраленнән район үзәге — Урыссу штп) р-ннары оештырыла.

РСФСР ЮС Президиумының 1938 ел 4 август Указы б-н Казан авыл р-ны таркатыла, һәм Столбище (Казан авыл, Лаеш, Питрәч р-ннарының бер өлешеннән), Юдино (1958 нең 16 июленнән — Зеленодольск; Казан авыл һәм Дөбъяз р-ннары), Олы Тархан (Тәтеш һәм Будённый р-ннары), Чепья (Балтач р-ныннан) р-ннары төзелә. 1938 ел ахырына районнар саны 63 кә җитә.

РСФСР ЮС Президиумының 1944 ел 19 февраль Указы нигезендә ТАССРда 12 район бүлгәләнеп 7 яңа район: Подберезье (Кайбыч р-ның бер өлешеннән), Чүриле (Арча, Саба р-ннарыннан), Корноухово (1946 ның 5 апреленә кадәр — Солтан; Балык Бистәсе, Лаеш р-ннары), Юхмачы (Әлки, Кузнечиха р-ннары), Ямаш (Яңа Чишмә, Акташ р-ннары), Матвеевка (Минзәлә, Калинин р-ннары), Морт (1944 нең 8 июненә кадәр — Костенеево; Алабуга р-ныннан) р-ннары оештырыла. 1940 еллар уртасына ТАССРда 70 район исәпләнә.

1950 еллар уртасында адм. берәмлекләр саны кими башлый. РСФСР ЮС Президиумының 1954 ел 22 ноябрь Указы б-н Корноухово, Матвеевка, Морт р-ннары; 1956 ел 17 май Указы б-н Подберезье, Чүриле; 1956 ел 7 декабрь Указы б-н Юхмачы, Ямаш; 1958 ел 16 июль Указы б-н Кызыл Армия, Тельман, Тәмте, Тымытык, Чепья; 1959 ел 26 март указы б-н Акташ, Кызыл Йолдыз, Лениногорск, Столбище; 1959 ел 12 октябрь Указы б-н Әтнә, Олы Тархан, Калинин, Теләче, Чынлы, Яңа Юл; 1960 ел 28 октябрь Указы б-н Красный Бор һәм Кузнечиха р-ннары бетерелә.

Партия һәм дәүләт җитәкчелеге органнарының җитештерү принцибы буенча тамырдан үзгәртеп корылуы сәбәпле, районнар авыл һәм сәнәгать р-ннарына бүленә. РСФСР ЮС Президиумының «Татарстан АССРда районнарны берләштерү турында»гы 1963 ел 1 февраль Указы нигезендә ТАССРда 29 район: Әгерҗе, Азнакай, Аксубай, Актаныш, Алексеев, Апас, Әлки, Балтач, Балык Бистәсе, Баулы, Беренче Май, Биектау, Биләр, Бондюг, Дөбъяз, Зәй, Кайбыч, Кама Тамагы, Кукмара, Лаеш, Мөслим, Норлат, Тәкәнеш, Тукай, Чүпрәле, Ширәмәт, Югары Ослан, Ютазы, Яңа Чишмә р-ннары таркатыла. Алар урынына, берләштерелеп, чикләре үзгәргән 17 авыл районы: Алабуга (Әгерҗе, Бондюг, Алабуга р-ннары тулысынча; Әгерҗе ш. һәм Бондюг штп керми, алар Алабуга шәһәр советы карамагына бирелә), Арча (Арча, Балтач, Тукай р-ннары тулысынча; Биектау р-ның бер өлеше), Әлмәт (Азнакай һәм Әлмәт р-ннары тулысынча; Азнакай һәм Актүбә штп лары керми, алар Әлмәт шәһәр советы карамагына күчә; Беренче Май, Зәй, Яңа Чишмә р-ннарының бер өлеше һәм Рус Акташы штп), Бөгелмә (Баулы, Бөгелмә,

Ютазы р-ннары тулысынча; Баулы, Карабаш, Урыссу штп лары керми, алар Бөгелмә шәһәр советы карамагына бирелә), Буа (Кайбыч, Чүпрәле р-ннары тулысынча; Апас һәм Буа р-ннарының бер өлеше), Зеленодольск (Дөбъяз, Зеленодольск, Норлат, Югары Ослан р-ннары тулысынча; Васильево, Карамалы Тау, Юдино штп лары керми, алар Зеленодольск шәһәр советы карамагына күчә; Биектау р-нының бер өлеше), Куйбышев (Әлки һәм Куйбышев р-ннары тулысынча), Лениногорск (Лениногорск р-ны тулысынча; Беренче Май р-нының бер өлеше; Зелёная Роща һәм Шөгер штп лары), Мамадыш (Мамадыш р-ны тулысынча; Балык Бистәсе, Тәкәнеш р-ннарының бер өлеше; Лубян штп), Минзәлә (Актаныш һәм Минзәлә р-ннары тулысынча; Мөслим р-нының бер өлеше; Дербёшка штп), Октябрь (Аксубай, Октябрь р-ннары тулысынча; Беренче Май, Биләр р-ннарының бер өлеше), Питрәч (Лаеш, Питрәч р-ннары тулысынча; Биектау, Балык Бистәсе р-ннарының бер өлеше; Лаеш штп), Саба (Кукмара, Саба р-ннары тулысынча; Тәкәнеш р-нының бер өлеше; Кукмара һәм Шәмәрдән штп лары), Сарман (Сарман р-ны тулысынча; Зәй һәм Мөслим р-ннарының бер өлеше), Тәтеш (Кама Тамагы, Тәтеш р-ннары тулысынча; Апас һәм Буа р-ннарының бер өлеше; Кама Тамагы һәм Куйбышев Затоны штп лары), Чаллы (Чаллы р-ны тулысынча; Зәй һәм Ширәмәт р-ннарының бер өлеше; Зәй, Түбән Кама һәм Яңа Зәй штп лары Чаллы шәһәр советы карамагына бирелә), Чистай (Алексеев, Чистай р-ннары тулысынча; Биләр, Ширәмәт, Яңа Чишмә р-ннарының бер өлеше) р-ннары; 1963 нең 27 августында Азнакай (Әлмәт шәһәр советы составыннан чыгарылган Азнакай һәм Актүбә штп лары керә) сәнәгать р-ны оештырыла.

Мондый бүленешнең нәтиҗәсе аз була. 1964 нең язынnan районнарны яңадан бүлә башлыйлар. РСФСР ЮС Президиумының 1964 ел 4 март Указы б-н Алексеев (Чистай, Куйбышев р-ннарыннан), Апас (Буа, Зеленодольск, Тәтеш р-ннары), Әгерҗе (Алабуга р-нының бер өлешеннән) авыл р-ннары төзелә; 1965 ел 12 гыйнвар Указы б-н Азнакай сәнәгать р-ны таркатыла, һәм Азнакай (Әлмәт, Бөгелмә р-ннарыннан), Аксубай (Октябрь р-ныннан), Актаныш (Минзәлә р-ны), Әлки (Куйбышев р-ны), Балтач (Арча р-ны), Балык Бистәсе (Мамадыш, Питрәч р-ннары), Баулы (Бөгелмә р-ны), Биектау (Зеленодольск, Питрәч р-ннары), Кама Тамагы (Апас һәм Тәтеш р-ннары), Кукмара (Мамадыш, Саба р-ннары), Лаеш (Питрәч р-ны), Мөслим (Сарман р-ны), Түбән Кама (Чаллы, Чистай р-ннары), Чирмешән (Лениногорск, Октябрь р-ннары), Югары Ослан (Апас, Зеленодольск р-ннарыннан) р-ннары барлыкка килә. Элек шәһәр советы карамагында булган шәһәр тибындагы посёлоклар, шәһәр советларыннан чыгарылып, районнар составына кушыла: Азнакай, Актүбә — Азнакай р-нында; Дербёшка — Актаныш; Бондюг — Алабуга; Баулы, Урыссу — Баулы; Васильево, Карамалы Тау, Юдино — Зеленодольск; Кама Тамагы, Куйбышев Затоны — Кама Тамагы; Кукмара, Лубян — Кукмара; Лаеш — Лаеш; Түбән Кама — Түбән Кама, Зәй һәм Яңа Зәй Чаллы р-нында. Гамәлдәге авыл р-ннары районнар дип үзгәртелә.

Соңрак РСФСР ЮС Президиумының 1966 ел 30 декабрь Указы б-н Буа р-ныннан — Чүпрәле; Әлмәт, Сарман, Чаллы р-ннарыннан — Зәй (1972 ел 1 нояб. Указы); Чистай р-ныннан — Яңа Чишмә (1983 ел 26 апр. Указы), Алабуга р-ныннан — Менделеев р-ны (1985 ел 15 авг. Указы); ТАССР ЮС Президиумының 1990 ел 25 октябрь Указы нигезендә Арча р-ныннан — Әтнә, Баулы р-ныннан — Ютазы (1991 ел 6 апр. Указы), Апас р-ныннан — Кайбыч (1991 ел 19 апр. Указы), Саба р-ныннан Теләче р-ны (1991 ел 4 окт. Указы) бүленеп чыга.

2010 елда ТР терр-ясе 43 районга: Азнакай, Аксубай, Актаныш, Алабуга, Алексеев, Апас, Арча, Әгерҗе, Әлки, Әлмәт, Әтнә, Баулы, Балтач, Бөгелмә, Буа, Биектау, Балык Бистәсе, Зәй, Кайбыч, Кама Тамагы, Кукмара, Лаеш, Лениногорск, Мамадыш, Менделеев, Минзәлә, Мөслим, Нурлат, Питрәч, Саба, Сарман, Спас, Тәтеш, Тукай, Теләче, Түбән Кама, Чирмешән, Чүпрәле, Чистай, Югары Ослан, Ютазы, Яңа Чишмә, Яшел Үзән р-нарына бүленә. *Казан* һәм *Чаллы* шәһәрләре дә районнарга бүленә.

*С.А.Фәйзуллин.*

**«РАЙО́Н ГАЗЕ́ТАСЫНА ЯРДӘМГӘ́»**, иҗтимагый-сәяси журнал. КПССның Татарстан өлкә комитеты органы. 1947–49, 1957 елларда Казанда татар телендә нәшер ителә.

**РАЙО́Н МӘХКӘМӘЛӘРЕ́**, гомуми юрисдикциядәге мәхкәмә органнары, РФ мәхкәмә системасының төп буыны. «Мәхкәмә турында» 1917 ел 22 ноябрь 1 нче, 1918 ел 18 февраль 2 нче һәм 1918 ел 22 июнь 3 нче декретлар нигезендә халык мәхкәмәләре буларак оештырылалар. Татарстанда кантоннар (1930 га кадәр), районнар (1930 дан) һәм районнарга бүленмәгән шәһәрләр терр-яләрендә гамәлдә булалар. Алар җинаятьчелек һәм гражданлык эшләрен, ш.у. билгеле бер терр-ядә халык судьялары һәм ике халык утырышчысы составындагы мәхкәмәнең 1 нче инстанциясе рәвешендә, адм. тәртип бозулар турындагы кайбер эш категорияләрен карыйлар. Баштарак халык судьялары Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның җирле советлары тарафыннан, 1936 дан — турыдан-туры район һәм шәһәр халкы тарафыннан гомуми, тигез һәм туры сайлау хокукы нигезендә, яшерен тавыш бирү юлы б-н 3 елга (1958 гә кадәр), 5 елга (1958–89), 1989 дан — халык депутатларының югары баскычтагы советлары тарафыннан 10 елга сайлана. Халык утырышчылары эш яки яшәү урыннары буенча гражданнар җыелышларында 2 елга (1958 гә кадәр), 2,5 елга (1958–89), 5 елга (1989 дан) сайлап куела. 1997 нең 1 гыйнварыннан халык мәхкәмәләре, «Россия Федерациясенең мәхкәмә системасы турында» 1996 ел 31 декабрь Федераль конституцион законына нигезләнеп, Р.м. дип үзгәртелә. Федераль мәхкәмәләргә карыйлар. Р.м. судьялары чикләнмәгән вәкаләтләр срогы б-н РФ Президенты тарафыннан билгеләнәләр. Үз гамәлләре чикләрендә Р.м. 1 нче һәм 2 нче инстанцияләр эшләрен карыйлар һәм закон буенча билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар. Үзләренә туры килгән мәхкәмә районында мировой судьяларга карата югары мәхкәмә инстанциясе һәм респ-каның Югары мәхкәмәсенә карата түбән инстанция булып торалар.

*Е.Б.Долгов.*

**РА́ЙХЛИН** Вадим Абрамович (26.7.1938, Казан), схемотехника һәм системотехника өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1997), проф. (1998). 1962 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. Хезмәтләре цифрлы схемотехникага һәм системаларны конструктив модельләштерүгә карый. Р. кыска ешлыклы биполиномиаль фильтрлар тибын ача, аларның матем. теориясен төзи һәм, шуңа нигезләнеп, вакытка карата яхшы реакцияле һәм артык катлаулы булмаган конструктив ясалма линияләр теориясен эшли. Цифрлы автоматка объектлы билгеләмә бирә, интернатив режимда нәформаль биремнәр буенча автоматлар синтезлауның рейм-продукцияле юлын үстерә; автоматның динамикада дөрес эшләвен тәэмин итүче эзлекле псевдосинхрон схемалар тибын ача. Логикалы истә калдыручы операцион тирәлекләрнең һәм алар нигезендә матрицалы ассоциатив процессларның конструктив теориясен эшли, картографик мәгълүматны ике үлчәнешле ассоциатив саклау ысулын ача; мәгълүмат системалары б-н идарә итүнең параллель системаларына хас булган закончалыкларны ачыклый.

Х е з м.: Синтез искусственных линий в пространствах, отображающих числовые последовательностей // Радиотехника и электроника. 1972. Т. 17, № 5; Конструктивное моделирование систем. К., 2005; Основы цифровой схемотехники. К., 2006.

**«РАКЕ́ТА»**, туплы хоккей буенча ирләр командасы. 1958 елда оештырыла, 1996 га кадәр Казан оптика-механика з-дының «Ракета» хоккей клубы каршында, 1996–2008 дә — Казанның Совет р-ны хакимияте каршындагы «Ракета» хоккей клубы» коммуналь учреждениесе, 2008 дән «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятенең ТР иҗтимагый дәүләт оешмасы каршында («Динамо-Казан» итеп үзгәртелә). 1964–71 дә СССР чемпионатында «А» классының 1 нче төркемендә, 1971–79 да РСФСР беренчелекләрендә һәм Профсоюзларның Бөтенсоюз үзәк советы Кубогы уенында катнаша, 1979–81 дә Россия (1993 кә кадәр СССР) чемпионатының 2 нче, 1981–96 да 1 нче, 1996 дан югары лигасында. Баш тренерлары — Е.Э.Флейшер (1958–66), И.Г.Бохараев (1967–71, 1979–82), И.И.Яшин (1983), Г.И.Кузовков (1985), Ю.Г.Гаврилов (1987, 1999–2000), А.П.Теняков (1987–89, 1996–98), И.К.Йосыпов (1989–92), О.А.Севрюгин (1992–96), С.Е.Лихачёв (2000–01), И.А.Фәсхетдинов (2001–02), В.Н.Иевлев (2003–08), А.В.Стук (2008–10, 2012–13), В.В.Янко (2010–12, 2013–14), Д.А.Щетинин (2014 тән). Иң югары казанышлары: Россия чемпионатының 1 нче лигасы чемпионы (1996), Викинглар кубогы (көмеш медаль,

2000, Норвегия), мини-хоккей буенча Россия чемпионаты (бронза медаль, 2001) призёры, Коми губернаторы кубогы иясе (2000), Россия чемпионатында бронза медаль (2009, 2013), Россия кубогы (2009, 2013), Чемпионнар кубогы (2009), Дөнья кубогы (2010) иясе, Россия чемпионы (2011), Россия чемпионатында көмеш медаль алучы (2012).

**«РАКИ́ТА»**, эре кара җимеш төрендәге слива сорты. 1978 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшерену ин-тының бакчачылык бүлегендә А.С.Вологдина һәм Л.А.*Севастьянова* тарафыннан чыгарыла. Өлгерү сроклары уртача; салкынга һәм корылыкка чыдам, авыруларга һәм корткычларга бирешмәүчәнлеге уртача; үзеннән серкәләнә. Агачы нык үскән, уртача куелыктагы пирамидаль таралып торган ябалдашлы. Җимеше чыбыкчаларында һәм сөңгечекләрдә үсә. Кәүсәсенең кабыгы һәм төп ботаклары коңгырт сары. Яфраклары куе яшел, ялтыравыклы, уртача зурлыкта, озынча-йомыркасыман. Җимешләре вак (10–12 *г*), түгәрәк-озынча формада, куе зәңгәр төстә, куе сары куныклы. Җимшәне яшел-сары төстә, уртача сусыл, тыгыз, тәме әчкелтем-баллы. 4–5 елдан җимеш бирә башлый. Бер агач 50 *кг* га кадәр җимеш бирә. Татарстанда 1988 дә районлаштырылган.

*В.А.Наумов, Л.А.Севастьянова.*

**РАКИ́ТНИК**, т а л - т и р ә к (Cytisus), кузаклылар семьялыгыннан яфрагын коючан, сирәк кенә мәңге яшел куаклар, зур булмаган агачлар ыругы. 50 дән артык төре билгеле, Евразиядә, Төньяк-Көнбатыш Африкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — рус Р.ы (C. ruthenicus) барлык районнарда да очрый. Нарат урманнарында, урман аланнарында, далаланган сөзәклекләрдә үсә. 40–200 *см* биеклектәге куак, чыбыксыман ботаклы. Яфраклары чиратлашкан, өчәрле, өске ягы — кара яшел, шома, аскы ягы — көмешсыман-соры, ефәксыман куе төкчәле. Күбәләк чәчәкле, алтынсу-сары төстә, чәчәкләре 2–5 әрләп яфрак куентыгында урнашкан. Җимеше — ачылучан кузак. Май-июньдә чәчәк ата. Җимешләре августта өлгерә. Орлыктан һәм тамыр үргеннәреннән үрчи, төптән кабат үсеп чыга. Яктылык яратучан, корылыкка, суыкка чыдам. Составында фәнни медицинада кулланылучы цитизин алкалоиды бар. Халык медицинасында яфрак һәм җимешләренең төнәтмәсе йөрәк авырулары вакытында һәм камаштыручы чара буларак кулланыла. Декоратив, баллы үсемлек.

**РА́КОВ** Евгений Дмитриевич (27.12.1927, Алабуга кантонының Бондюг пос., хәзер Менделеев ш.), авиаконструктор, ракеталар төзелеше белгече, Ленин бүләге лауреаты (1978). 1950 елда Мәскәү авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, конструкторлык бюросында (Миасс ш.) эшли, 1961 дән Воткинск машиналар төзү з-дында тәҗрибә КБ башлыгы һәм з-дның баш конструкторы; баллистик ракеталарны серияләп җитештерүне оештыручы. 1968 дән «Регион» ФҖБнең (Мәскәү) баш конструкторы һәм ген. директор урынбасары. Ленин бүләге Хәрби-диңгез флотына яңа буын кораллар эшләгәне өчен бирелә. Уйлап табуга 300 дән артык авторлык таныклыгы һәм патенты бар. 1950 дә авиамодель спорты буенча 5 дөнья рекорды куя. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Воткинск шәһәренең мактаулы гражданы.

**РАКО́ВИЧ** Андрей Николаевич (29.7.1815, Украина — 28.3.1866, Казан), рәссам, пейзажлы нәкышь академигы (1847). САдә перспективалы нәкышь һәм пейзаж нәкыше классы буенча проф. М.Н.Воробьёвта укый (1834–36). «Полиция күпере күренеше» картинасы өчен рәссам дәрәҗәсенә һәм көмеш медальгә лаек була. 1838 елда — С.-Петербургның шәһәр төзелеше ком-тында сызымчы, 1839–41 дә Сембер гимназиясендә рәсем укытучысы булып эшли. 1841 дән — Казандагы Икенче ир балалар гимназиясендә, 1843–63 тә Казан ун-тында, бер үк вакытта Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында (1847–48) һәм Мария хатын-кызлар уч-щесендә (1862) рәсем дәресләре укыта. Р.ның югары профессиональлек, зур талант, интеллектуаль киңлек һәм тирәнлек б-н алып барылган пед. һәм иҗат эшчәнлеге 19 йөзнең 1 нче яртысында Казанның сәнгати мәдәниятенә моңарчы күрелмәгән яңа сыйфатлар өсти. 1845 тә Казанга килгән СА Президенты герцог М.Лейхтенбергскийга Р.ның аны нәкышь академигы дәрәҗәсенә ирештергән «Казандагы Изге Пётр соборы» картинасы (1845) бүләк ителә. Р. соңрак *Казан университетының Нәфис сәнгать һәм борыңгы истәлекләр музее* тупланмалары составына кергән рәсем классы тупланмасын төзи. Француз теленнән Ш.Клеманның «Леонардо да Винчи, Рафаэль, Микеланджело» хезмәтен тәрҗемә итә, кереш өлешендә сәнгатьнең кеше тормышындагы әһәмияте турында үз карашларын яза. Р.ның нәкышь иҗаты, нигездә, шәһәр пейзажына багышланган; аның картиналарындагы композицияләр манзарасында соңгы романтизм сыйфатларындагы һава мохите яктылык күләгәсе муллыгы б-н берләштерелгән. Төп әсәрләре: «Никола Гостинодворский чиркәве б-н Казан күренеше» (1846), «Подлужный урамы күренеше», «Ослан тавыннан Казан күренеше» (икесе дә — 1850 еллар), «Ташу вакытында Казан күренеше» (1863).



А.Н. Р а к о в и ч. «Казандагы Изге Пётр соборы». 1845. Рус музее. С.-Петербург.

СА күргәзмәсендә катнаша (1861). Рәссамның әсәрләре Третьяков галереясында, Рус музеенда, Дәүләт Тарих музеенда, ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.

Х е з м.: Краткий опыт линейного черчения. К., 1861.

*Әд.:* К о р н и л о в П.Е. Казанский художник А.Н.Ракович (1815–1866). К., 1926; К л ю ч е в с к а я Е.П. Изящные искусства в Казанском университете. К., 2008.

*Е.П.Ключевская.*

**РА́КОВО** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 27 *км* көньяктарак, Чынлы елгасы буенда. 2010 елда 348 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1723 тән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче чирегендә халкы — дәүләт, 1835 тән удел крәстияннәре (1860 ларга кадәр) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Р.да Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе, 7 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1241,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1795 тә — 232, 1859 да — 356, 1897 дә — 639, 1913 тә — 846, 1920 дә — 879, 1926 да — 1026, 1938 дә — 1228, 1949 да — 928, 1958 дә — 989, 1970 тә — 926, 1979 да — 808, 1989 да — 467, 2002 дә — 364 кеше.

**РАКШАСЫМАННА́Р** (Coraciiformes), кошлар отряды. 200 гә якын төре билгеле. Башлыча тропик һәм субтропикларда таралганнар. ТР терр-ясендә 3 төре: күк карга (Coracias garrulus), гади яр чыпчыгы (Alcedo atthis), сары корташар (Merops apiaster) бар. Оя коручы күчмә төр. Апрель ахырыннан октябрьгә кадәр очрый. Гәүдә төзелеше тыгыз. Ачык төстә, чуар, металлсыман ялтыравыклы. Башы зур. Томшыгы туры яки аз гына аска таба бөгелгән. Тәпиләре кочсез, дүрт бармаклы. Җенси һәм олыгаю диморфизмы бик сизелми. Р. аерым парлар яки колония булып яшиләр. Моногамнар. Агач куышларына, өннәргә оялыйлар. Ялтыравыклы 4–10 ак йомырка салалар. Эре бөҗәкләр, сирәк кенә җир-су хайваннары, сөйрәлүчеләр, вак балык б-н тукланалар. Р. елга 2 тапкыр йонналарын коялар: яз башында (тулысынча) һәм көзен (өлешчә). Барлык төрләре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**РАМА́ЕВ** Гаяз Галиәскәр улы (6.4.1921, Уральск ш. — 26.1.1943, Сталинград ш.), Сов. Союзы Герое (10.1.1944, үлгәннән соң), лейтенант. 1923–32 һәм 1937–40 елларда Саратов шәһәрендә яши (бүленеп: 1932–37 дә — Уральскида). Саратовта «Универсал» машина төзелеше з-дында эшли. 1940 тан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 128 нче ук-

чы полкның разведчиклар взводы командиры (64 нче армиянең 29 нчы укчы дивизиясе). Сталинград һәм Дон фронтлары гаскәрләре составында Сталинград сугышында (1942–43) катнаша. Сталинград янындагы сугышта батырлык күрсәтә: 1943 нең 16 гыйнвар төненә каршы Р. җитәкчелегендәге взвод Песчанка авылыннан көньяк-көнбатыштарак дошман тылына үтеп керә, дистәләрчә солдатны юк итә, 60 ка якын солдатны әсир ала. 26 гыйнварда Югары Ельшанка авылы өчен сугышта Р. разведчиклар төркеме б-н дошманның 4 ут ноктасын кулга төшерә; шул сугышта һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медаль б-н бүләкләнә. Саратов шәһәрендәге бер урам Р. исемен йөртә.


*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

**РАМАЗА́Н** (гарәп. رمضان), мөселман ай календареның тугызынчы ае. Р.да беренче мөселманнар җәмгыяте Мәккәдән Мәдинәгә *һиҗрәт* кылганнан соң 17–18 ай үткәч, Мөхәммәд пәйгамбәр карары б-н ураза тоту гамәлгә кертелә. Мөселман риваятьләре буенча, Р.ның 27 нче кичендә Мөхәммәд пәйгамбәргә беренче вәхи иңә (әлеге кичтә — *Кадер кичендә* Аллаһ кешеләр язмышы турында карарлар чыгара). Шулай ук Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы әл-Хөсәеннең туган (6 нчы), Пәйгамбәрнең хатыны Хәдичәнең вафат булган (10 нчы), Бәдер сугышы (17 нче), Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккәгә аяк баскан (19 нчы), беренче дүрт хак хәлифәнең берсе Галинең туган (22 нче) һәм вафат булган (21 нче) көннәре Р. аена туры килә. Р. ае Ураза гаете б-н тәмамлана.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**РАМАЗА́Н БӘЙРӘМЕ́**, к. *Ураза бәйрәме.*

**«РАМАЗА́Н»**, 1994 елда Казанның Елга аръягында арх. С.С.Айдаров проекты буенча салынган мәчет. Йортлар арасында койма б-н әйләндереп алынган мәйданда урнашкан. Манарасы түбәнең үзәгеннән күтәрелгән, планда төньяктан көньякка сузылган ике катлы, турыпочмаклы кирпеч бина. Беренче катның көньяк өлешендә хатын-кызлар өчен намаз уку залы, төньякта икенче катка алып менүче өч маршлы баскыч һәм ир-атлар өчен намаз уку залы урнашкан, көнчыгыш һәм көнбатыш якта хатын-кызлар һәм ир-атлар өчен аерым ишекләр уелган. Алар чишенү, тәһарәт, хуҗалык бүлмәләре булган аерым вестибюльләргә алып керә. Икенче катта ян-яктагы хуҗалык бүлмәләре арасындагы коридор анфилада аша тоташкан ир-атлар залына илтә. Көньяк дивардагы чыгынты михрабны төп зал гөмбәз б-н ябылган. Кыеклары кисешкән һәм салмак кына бөгелгән түбә уртасында үзәге һәм дүрт почмагы чатырлар б-н капланган айлар б-н бизәлгән ике ярусл квадрат манара күтәрелә. Манарага икенче каттагы тар баскыч аша мендләр. Яндырылган кирпеч төсендәге диварлар ак төскә буялган кыек сызыклы чыгынтылар һәм стильләштерелгән татар халык орнаменты төшерелгән декор. бизәкләр б-н ярашып тора. «Р.» мәчете манарасы формасы б-н Дары заводы бистәсе мәчете манарасына охшатып эшләнгән.



«Рамазан» мәчете. Казан. 1994.
Архитекторы С.С.Айдаров.

*Әд.:* Мечети Татарстана / Сост. Х.Г.Надырова, Р.Р.Салахиев, Р.Р.Хайрутдинов. К., 2000.

*Х.Г.Надыйрова.*

**РАМАЗА́НОВ** Әхмәтгәрәй Насыйбулла улы (Ромазанов Сергей Николаевич) (25.10.1901, Ульянов өлкәсе, Яңа Малыклы р-ны Лабит а. — 3.12.1979, Мәскәү), авиация генерал-лейтенанты (1944). Ф.Энгельс исем. сәяси составның белемен күтәрү курсларын (Петроград, 1922), очучылар курсларын (1934), Эшче-Крәстиян Кызыл Армиясенең Н.Е.Жуковский исем. Хәрби-һава академиясе каршындагы белем күтәрү курсларын (Мәскәү, 1937), Югары сәяси состав курсларын (Мәскәү, 1941) тәмамлый. 1914–18 елларда туган авылында батраклыкта. 1919 дан Кызыл Армия сафларында. Гражданнар сугышы елларында Польша фронты сугышларында (1920) катнаша. Таҗикстанда басмачыларга каршы, 1939 да Халхин-Гол елгасы буенда япон милитаристларына каршы сугыша. 1941 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында: авиациядә өлкән инспектор, Ерак Көнчыгыш фронтындагы сәяси бүлекнең СССР Хәрби Һава Көчләре штабы башлыгы урынбасары. 1942 дән Брянск фронты хәрби комиссары, 1942–47 дә сәяси бүлек командирының урынбасары һәм СССР Хәрби Һава Көчләре 2 нче һава армиясенең Хәрби советы әгъзасы. 1947–59 да СССР Һава һөҗүменә каршы оборона һәм Еракка очышлар авиациясенең Ерак Көнчыгыш, Баку округларындагы Хәрби Һава Көчләре Хәрби советы әгъзасы. 1923–24 тә Петроград Советы депутаты. Ике Ленин ордены, биш Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Суворов, 1 нче дәрәҗә Богдан Хмельницкий, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Годы и люди // Вестн. воздушного флота. 1957. № 11–12; 1958. № 1–4.

*Әд.:* К о н е в И.С. Записки командующего фронтом. 1943–1944. М., 1989.

*Б.А.Канеев.*

**РАМАЗА́НОВ** Габдерәшит (19 йөз ахыры — 1919), шагыйрь. 1910–14 елларда шигырьләрен «Шура» ж-лында, «Йолдыз», «Кояш», «Идел» һ.б. г-таларда бастыра. «Габдерәшит



Г.Г.Рамаев.



Ә.Н.Рамазанов.

Рамазанов шигырьләре» (1910), «Дәртле уку» (1912), «Уку гөле» (1912) җыентыклары авторы.

*Әд.:* Татар шигърияте: XX гасыр башы. К., 2004.

**РАМАЗА́НОВ** Гыйлемдар Җиһандар улы (16.6.1923, БАССРның Бәләбәй кантоны Иске Балак а. — 25.8.1993, Уфа), шагыйрь, әдәбият белгече, филол. фән. д-ры (1966), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1983). Башкорт пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1949), Бөре шәһәрендә укытучылар ин-тында һәм пед. уч-щесында башкорт теле һәм әдәбияты укыта. 1955 елдан «Совет Башкортстаны» г-тасының баш мөхәррире. 1958–89 да СССР ФАнең Башкортстан ф-лы Тарих, тел һәм әдәбият ин-тында фәнни хезмәткәр. Матбугатта 1937 дән басыла башлый. Әсәрләрендәге үзәк тема — Бөек Ватан сугышы. Шагыйрь сугышчы геройның күңел кичерешләрен ачып бирә («Беҙҙең быуын», Уфа, 1947; «Яҡты юлдар», Уфа, 1952; «Һөйөү һүҙе», Уфа, 1955; «Йәшлек юлдары», Уфа, 1958 җыентыклары), сугыш эпизодларын күз алдына китерә (рус теленә тәрҗемәдә «Разговор с отцом», Уфа, 1966; «Разговор гор», Уфа, 1967; «Две реки», Уфа, 1978 поэмалары), яу һәм хезмәт батырларына дан җырлый («Атай янында», Уфа, 1966; «Заман еле», Уфа, 1970; рус теленә тәрҗемәдә «Полвека», М., 1974; «Илле йәштәгеләр», Уфа, 1975; рус теленә тәрҗемәдә «В стране Салавата», М., 1975; «Звёзды за бой, звёзды за труд», М., 1979 җыентыклары). Р.ның поэзиясенә публицистик интонация һәм ачык гражданлык позициясе хас. Балалар өчен язылган шигырь-поэмалары да патриотизм һәм гражданлык хисләре б-н сугарылган («Гәҗәп сәйәхәт»,Уфа, 1959; «Ерән ҡашҡа», Уфа. 1975 җыентыклары). 1980 еллар ахыры — 1990 еллар башы иҗат чорында Р. үткән вакыйгаларга тәнкыйди күзлектән бәя бирә. Шигырьләрендә Ватан, халык, дуслык, милләт кебек төшенчәләргә күбрәк мөрәҗәгать итә, заман психологиясен ачарга тырыша. Р. — әдәбият белгече буларак та танылган шәхес. Аның башкорт әдәбияты турында матбугатта басылган мәкаләләреннән тыш, «Башҡорт поэзияһында совет кешеһе образы» (Уфа, 1956), «Мәжит Ғафури ижады» (Уфа, 1965), «Сәйфи Кудаш: Әдәби портрет» («Сайфи Кудаш: Литературный портрет», М., 1989) хезмәтләре бар. Башкорт теленә А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Н.А.Некрасов әсәрләрен тәрҗемә итә. Р.ның әсәрләре украин, белорус, казакъ, кыргыз, чуаш, грузин телләре-

нә тәрҗемә ителгән. БАССРның Салават Юлаев исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1982). Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Һайланма әҫәрҙәр: 2 томда. Өфө, 1972–73; Алтмыш аҙым.Өфө, 1983; Яшьлектә кунакта. К., 1983; Хәтер. Өфө, 1998.

*Әд.:* Х ө с ә й е н о в Ғ. Шағирҙар. Өфө, 1981; С а ф у а н о в С. Тынғы белмәй торған юлсы мин // Ағиҙел. 1983. № 6; Яҙылмаған китап: иҫтәлектәр. Өфө, 1998.

**РАМАЗА́НОВ** Марат Даут улы (28.4.1939, Уфа ш.), математик, физика-матем. фән. д-ры (1977), проф. (1978), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1983). 1961 елда Мәскәү ун-тын тәмамлый, СССР ФА Себер бүлегенең Математика ин-тында эшли (1965–71). 1971–88 дә Башкорт ун-тының дифференциаль тигезләмәләр каф. мөдире, 1988 дән РФА Уфа Гыйльми үзәгенең матем. ин-тында. Хезмәтләре аерым чыгарылмалы дифференциаль тигезләмәләргә, функциональ анализга һәм реаль үзгәрешле функцияләр теориясенә, хисаплау математикасына, якынча интеграллау теориясенә һәм аны куллануга карый. Р. матем. физиканың кырый мәсьәләләре куелышының тигәллеген тикшерә, дифференциаль тигезләмәләр өчен функциональ фәзалар классын ача, функцияләрне банах фәзаларындагы гиперөслекләрдән төгәл дәвам иттерү операторын исәпләп чыгара. Рәшәткәсыман кубатур формулаларны ирекле формаларның өлкәләре буенча интеграллау алгоритмын төзи.

Х е з м.: Лекции по теории приближённого интегрирования. Уфа, 1973; Теоремы о следах и продолжениях // Докл. РАН. 2002. Т. 382, № 6; Теоремы вложения и многомерные сплайны // Докл. РАН. 2007. Т. 413, № 2; To the Lp theory of Sobolev formulas // Sibirian Advances in Mathematics. 1999. V. 9, № 1.

**РАМАЗА́НОВ** Рәшит Газнави улы (20.2.1952, БАССРның Дүртөйле р-ны Яңа Биектау а.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007), техник фән. канд. (1992). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), «Үзбәкгазпром» (Ташкент) ҖБнең Үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясендә эшли. 1977 елдан ТатНИПИнефтьтә, нефть чыганакларын эшкәртү бүлеге мөдире (2004 тән). Дәүләт бүләге автоматлаштырылган проектлау технологияләре нигезендә нефть чыганакларын эшкәртү алымнарын булдыруда һәм сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

Х е з м.: Система разработки нефтяных месторождений горизонтальными скважинами // Геология, геофизика и разработка нефтяных месторождений. 1996. № 4 (автордаш); Планирование методов увеличения нефтеотдачи и стимуляции скважин по технологическим показателям эксплуатации // Нефтяное хоз-во. 2004. № 7.

**РАМАЗА́НОВ** Шиһабетдин Галим улы (20.12.1887, Саратов губ., Иске Карлыган а., хәзер Пенза өлкәсенең Лопатин р-ны — 25.10.1948, Казан), тел галиме, филол. фән. канд. (1944). 1924–25 елларда — Саратов, 1930–31 дә Әстерхан пед. техникумнарында укыта. 1934–47 дә Казан пед. ин-тында, бер үк вакытта, 1942–48 дә, СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, шул ук вакытта, 1943–45 тә, Казан ун-тында. Хезмәтләре татар грамматикасына, сүз ясалышы, лексикология, терминология, татар әдәби теле тарихы, сөйләм культурасына карый. Р. руслашкан алфавит төзүдә катнаша. Башлангыч һәм урта мәктәпләр өчен татар теле дәреслекләре һәм программалары авторы.

Х е з м.: Татар әдәби теленең орфография кагыйдәләре. К., 1934 (автордаш); Г.Тукай һәм хәзерге татар әдәби теле // Совет әдәбияты. 1946. № 10; Татар теле буенча очерклар. К., 1954.

*Әд.:* И с л а м о в Ф.Ф. Зур педагог та ул Ш.Рамазанов // Мәгърифәт, әдәбият һәм тарих сукмаклары буенча. К., 2002; Я к у п о в а Г. Шигап Алимович Рамазанов (к 90-летию со дня рождения) // Советская тюркология. 1978. № 1; Казанская лингвистическая школа / Сост. М.З.Закиев. К., 2008.

**РАМАЗА́НОВА** Дөрия Бәйрәм кызы (17.9.1938, Саба р-ны Пүкәл а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (1998), проф. (2008), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1997), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2012). Казан ун-тын тәмамлый (1963). СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1967–97), ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында (1997–2016) эшли. Хезмәтләре татар теле тарихына, лексикологиясенә, диалектологиясенә (Урта Кама төбәге, Көньяк-көнбатыш Башкортстан, Себер һәм Пермь татарлары сөйләшләре) карый. «Русча-татарча кыскача музыкаль атамалар сүзлеге»н («Краткий русско-татарский словарь музыкальных терминов», 1995), «*Урта Идел һәм Урал буе татар халкы сөйләшләре атласы*»н (1989, 2007), «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н (2003), ике китаптан торган «Татар халык сөйләшләре»н (2008), «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»н (2009), «Татар диалектларыннан сөйләү үрнәкләре»н (2011), «Татар сөйләшләреннән тезмә текст үрнәкләре»н (2013) һ.б.ны төзүчеләрнең берсе. ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2010).

Х е з м.: Себер диалектларыннан материаллар. Төмән, 2000; Татар теленең көнчыгыш диалектлары. Төмән, 2007; Татар сөйләшләрендә кешегә бәйләнешле лексика. К., 2013; Татар тарихи лексикологиясенә материаллар. К., 2016; Названия одежды и украшений в татарском языке в ареальном аспекте. К., 2002; Tartarica: Этнография. К.–М., 2008 (автордаш).

*Әд.:* Тюркологи Татарстана. М., 1997.

**РАНГАЗА́Р** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Мәллә елгасының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 11,6 *км*, бассейнының мәйданы 92 *км*$^2$. Сарман р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Рангазар авылының көнбатыш кырыенда, тамагы Рантамак авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 145 *м*, тамагыныкы — 90 *м*. Су җыелу мәйданында урман үсентеләре бөтенләй юк. Р.ның 1,1 дән 4,5 *км* га кадәр озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,2 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәенлек саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 82 *мм*, ташу вакытында су катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,14 *м*$^3$/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елгада суның күләме 0,95 млн. *м*$^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**РАНГАЗА́Р** (Алан Газар) авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 13 *км* көнчыгыштарак, Рангазар елгасы буенда. 2010 елда 393 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1782 гә кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рангазирова исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Р.да мәчет, мәктәп була. 20 йөз башында 2 ярма яргыч эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3459,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әлмәт-Муллино волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1870 тә — 751, 1897 дә — 992, 1920 дә — 1369, 1926 да — 1086, 1938 дә — 1080, 1949 да — 810, 1958 дә — 767, 1970 тә — 801, 1979 да — 602, 1989 да — 455, 2002 дә — 424 кеше.

**РАНТАМА́К** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 21 *км* көньяктарак, Мәллә елгасы буенда. 2010 елда 213 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1748 дән Токметево авылы буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рангазар-Тамак исеме б-н дә мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 503,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Кармалы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1870 тә — 156, 1920 дә — 342, 1926 да — 255, 1938 дә — 299, 1949 да — 334, 1958 дә — 367, 1970 тә — 423, 1979 да — 313, 1989 да — 188, 2002 дә — 184 кеше.

**РАПС** (Brassica napus var narus), әвернә чәчәклеләр семьялыгы *кәбестә* ыругыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр астөре; май бирә торган һәм терлек азыгы культурасы. Б.э.к. 4 нче меңьеллыктан, Россиядә 19 йөздән билгеле. Р.ның ике формасы бар: көзге һәм язгы Р., яисә кольза. Ужым һәм сабан шепкәнен бакча кәбестәсе б-н серкәләндерүдән барлыкка килә. Сабагы 50–150 *см* биеклектә. Үсемлек сары кунык б-н капланган. Розеткасыман яфраклары — каурыйсыман бүленмәгән, лирасыман һәм үзенчәлекле тар-

макланганнар, сабак яфраклары лирасыман (түбәнгеләре) һәм озынча ланцетсыман (югарыдагылары). Чәчәк оешмасы — чук. Чәчәкләре вак, сары, сирәгрәк ак төстә. Кузаклары озын (5–20 *см*), тар (3–4 *мм*). Ике формасы арасында кискен морфологик үзенчәлекләре юк. Көзге Р.ның салкынга чыдамлыгы түбән, корылыкны начар кичерә. Язгы Р. табигать шартларына таләпчән түгел. Көзге Р.ның вегетация чоры 270–300 тәүлек, язгы Р.ның — 80–100 тәүлек. Кулай туфраклар — туклыклы матдәләргә бай балчыклы туфрак. Р. орлыгының майлылыгы 41–49% ка җитә. Мае азык, сабын кайнату, текстиль, ягулык сәнәгатендә кулланыла. Түбе — терлек азыгы (гликозид кушылмаларын аерып алганнан соң). Көзге Р. терлек азыгы буларак кыйммәтле, Татарстанда көз ахырында яшел терлек азыгы алу өчен үстерелә. Язгы Р. май өчен игелә. Респ-ка терр-ясендә Р. 1980 нән яшел терлек азыгы буларак, 1987 дән орлыкка үстерелә. Көзге Р. үстерелә торган мәйдан 2014 тә — 30 мең *га*, язгы Р.ныкы — 71,877 мең *га*. Язгы Р. орлыгының уңышы 2013 тә 1 *га* дан 10,7 *ц*. Р. рәтләп чәчелә (рәт аралары 15 *см*); чәчү нормасы 1 *га* га 8–12 *кг*, орлыкларны күмү тирәнлеге 2–4 *см*. Аерым ысул б-н җыялар. Язгы Р.ның Татарстанда чәчү өчен тәкъдим ителгән сортлары: Ярвэлон (1990), Радикал (1994), Липецкий (1994), Ратник (1997), Ритм (2000), Герос (2001). Авырулары — альтернариоз, ялган ончыл чык. Корткычлар — рапс кисмәннәре, рапс яфрагашары, рапс чәчәгашары, җир борчалары һ.б. Көрәш чаралары: югары дәрәҗәдәге агротехника, инсектицидлар һәм фунгицидлар куллану.

*Әд.:* Г а р е е в Р.Г. Рапс — культура высокого экономического потенциала. К., 1996; ш у л у к. Рапс: состояние, тенденция развития, перспективы. К., 1998; Пути повышения эффективности возделывания масличных культур // Слагаемые эффективного агробизнеса: Обобщение опыта и рекомендации. Ч. 1. Земледелие и растениеводство. К., 2005.

*И.Н.Афанасьев.*

**РАСИ́Х** (псевд., чын фамилиясе Рәсүлев) Атилла Кадыйр улы (16.9.1916, Истанбул ш., Төркия — 9.5.1996, Казан), язучы, зоотехник, а.х. фән. канд. (1950). 1929 елдан Казанда яши. 1931 дә М.Вахитов исем. Казан сабын з-ды каршындагы ФЗӨ мәктәбенә укырга керә. 1934 кә кадәр з-дта эшли, күптиражлы «Вахитовец» г-тасы редакциясе каршындагы татар әдәби түгәрәгенә мавыгып йөри, шигырьләр, хикәяләр яза. Казан вет. ин-тын тәмамлый (1938). 1940 тан ТАССР Җир эшләре халык комис-тында зоотехник булып эшли. 1947–64 тә Казан вет. ин-тында доцент. Сугышка кадәр үк юмористик хикәяләре б-н таныла: «Касса янында» (1934), «Таныш кеше» (1938), «Кызыл чүлмәк» (1940). Бөек Ватан сугышы елларында матбугатта хикәяләре, очерклары, фронт темасын яктырткан язмалары басыла, разведчиклар турында «Бәхет орлыклары» (1945) мадаралы повесте дөнья күрә. Р.ның сугыштан соңгы иҗаты күбрәк авыл тормышын чагылдыра. Иң уңышлы әсәрләре — «Дустым Мансур» (1953; рус теленә тәрҗемәсе «Мой друг Мансур», М., 1973), «Язгы авазлар» (1963; рус теленә тәрҗемәсе «Весенние голоса», М., 1977) романнары. Р. татар прозасында беренчеләрдән булып фән дөньясын сурәтләргә алына. «Ике буйдак» (1965; рус теленә тәрҗемәсе «Когда расходятся пути», М., 1968, 2 нче басма, 1971; Татар акад. театрында әсәр буенча спектакль куела, 1967), «Сынау» (1981) романнарында институт хезмәткәрләре, фән өлкәсендә булган каршылыклар сурәтләнә. Маҗаралы сюжетларга кабат мөрәҗәгать итеп, Р. балалар өчен «Урланган хәзинә» (1961), «Маҗаралы повестьлар» (1966) китапларын яза. «Ямашев» (1 нче китап, 1968; рус теленә тәрҗемәсе 1975), «Айлы төннәр» (2 нче китап, 1977; рус теленә тәрҗемәсе «Лунные ночи», 1979), «Ямашев» (3 нче китап, 1984) роман-трилогиясендә татар революционеры Х.Ямашевның үзенчәлекле образын тудыра. Өч китаптан торган «Елларны чигерсәм» («Ишан оныгы», 1996; «Кәгазьдәгеләр һәм хәтердәгеләр», 1996; «Тыныч еллар күләгәсендә», 1996) романнарында Р., үзенең нәсел шәҗәрәсенә, балачак хатирәләренә нигезләнеп, драматик утызынчы һәм сугыш еллары чоры кичерешләрен сурәтли, күп кенә тарихи шәхесләрнең портретларын бирә. Э.Д.Эрвильинең «Тарихкача яшәгән малайның күргәннәре» («Приключения доисторического мальчика», 1953), А.Беляевның «Су кешесе» («Человек-амфибия», 1959) романнарын татар теленә тәрҗемә итә. ТАССРның Габдулла Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.


А.К. Расих.

Ә с ә р.: Әсәрләр: 3 томда. К., 1986–88; Сайланма әсәрләр. К., 2003.

*Әд.:* З а р и п о в а Р. Атилла Расих: Тормышы һәм иҗаты. К., 2006.

**РАТЁХИН** Константин Алексеевич (1893, Ярославль губ. — ?), профсоюз эшлеклесе. Сәнәгать академиясе тыңлаучысы (Мәскәү, 1928–31). 1900 еллар башыннан С.-Петербургта яши, слесарьлык-суүткәргеч торбаларны төзәтү остаханәсе өйрәнчеге. 1914 тә Петроград су үткәрүчеләр берлеген оештыруда катнаша. Беренче бөтендөнья сугышы башланганнан соң кулга алына, соңрак сугышка җибәрелә. 1915–17 дә Петроград, Мәскәү, Урал, Харьковта була. 1917 нең апреленнән Мәскәүдә, завод ком-ты секретаре, Замоскворечье р-н советы рәисе, Мәскәү шәһәр советы президиумы әгъзасы. 1923–26 да Казан шәһәре Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлар советы рәисе, ТАССР ҮБК Президиумы әгъзасы. 1926–27 дә Ташкентта СССРның Урта Азия буенча Хезмәт халык комис-ты вәкиле, 1927–28 дә «Лакокраска» тресты идарәсе рәисе урынбасары. 1931 дән Түбән Новгород шәһәрендә «Красное Сормово» з-ды директоры урынбасары.

*Р.Х.Әхмәтҗанов.*

**РА́ТНЕР** Александр Юрьевич (22.5.1934, Казан — 15.10.1994, шунда ук), невропатолог, мед. фән. д-ры (1970), проф. (1972), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1987, 1993). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1957), Казан ГИДУВының нерв авырулары клиникасында, 1961 елдан балалар неврологиясе кафедрасында, 1970 тән каф. мөдире. Хезмәтләре яңа туган балаларда нерв системасы зәгыйфьләнү очракларын өйрәнүгә карый. Балалар неврологиясендә яңа фәнни юнәлешкә — яңа туган балаларда туу вакытында барлыкка килгән нерв системасы зәгыйфьлеген, ш.и. арка мие зәгыйфьлеген өйрәнүгә нигез салучы. Р. тарафыннан балалар неврологиясендә аңа кадәр тасвирланмаган күзән җыеру халәте өйрәнелә. Балалар неврологиясе өлкәсендә аеруча зур хезмәт куйган өчен Чехословакия мед. ассоциациясенең Пуркенье медале б-н бүләкләнә (1978).

Х е з м.: Шейный остеохондроз и церебральные нарушения. К., 1970; Нарушения мозгового кровообращения у детей. К., 1983; Родовые повреждения нервной системы. К., 1985; Поздние осложнения родовых повреждений нервной системы. К., 1990.

*Әд.:* Р о з е н г а р т е н М.Ю. Генератор науки. Йошкар-Ола, 2000.

**РА́ТНЕР** Фаина Лазаревна (23.12.1941, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (1997), проф. (1999). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Казан ун-тының немец һәм француз телләре кафедрасында эшли башлый. 1999 елдан немец теле кафедрасында, 1997 дән Тел ин-тында (2008 гә кадәр директор). Хезмәтләре немец телен укыту методикасына, чит телләр өйрәнү тарихына, студентларны фәнни эшчәнлеккә әзерләү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Иностранные языки в дореволюционной высшей школе (На материале Казанского университета). К., 1983; В помощь изучающим немецкий язык. К., 1988; Научная деятельность студентов в системе многоуровневого образования за рубежом. К., 1997; Интегрированное обучение детей с ограниченными возможностями в обществе здоровых детей. М., 2007.

**РА́ТНЕР** Юрий Александрович (25.3.1895, Могилёв губ. Чаусы ш. — 20.12.1979, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1937), проф. (1938), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1940). Проф. В.Л.Боголюбов шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1920), Казан ГИДУВында, 1935–72 елларда хирургия һәм онкология каф. мөдире. 1926 дан ТАССР Туберкулёз диспансеры консультанты, Казанда үпкә туберкулёзын хирургия ысуллары б-н дәвалауга нигез салучы. Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан һәм Удмурт АССР эвакогоспитальләрендә баш хирург. ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгы баш онкологы (1945–60). Хезмәтләре яман шешләргә диагноз кую һәм аларны дәвалауга карый. Казан онкологлар мәктәбенә нигез салучыларның берсе, торакаль хирургия, урология, проктология, эндоскопия хезмәтләрен оештыручы.

Х е з м.: Гнойный плеврит и его лечение. К., 1935; Огнестрельное ранение груди. К., 1944; Неотлож-



Р.А. Ратникова.

ная хирургия живота. К., 1947; Забрюшинные опухоли. К., 1965.

*Әд.:* Профессор Юрий Александрович Ратнер // Казан. мед. журн. 1970. № 3.

**РА́ТНИКОВА** Римма Атлас кызы (1.5.1955, Шөгер р-ны Юлтимер а.), журналист, дәүләт эшлеклесе, ТР һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1995, 2010). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1977), «Комсомолец Татарии» г-тасында хәбәрче, бүлек мөдире булып эшли. 1985–89 елларда КПССның Казан шәһәре Ленин райкомы бүлек мөдире урынбасары, КПССның Казан шәһәр ком-ты инструкторы. 1989–98 дә «*Молодёжь Татарстана*» г-тасының баш мөхәррире. 1998–2004 тә «*Татаринформ*» мәгълүмат агентлыгы ген. директоры. 1995 тән ТРның Журналистлар берлеге рәисе. Үзгәртеп корулар, хәбәрдарлык, респ-каның яңа дәүләтчелеге формалашу һәм үсү шартларында Татарстан массакүләм мәгълүмат чаралары системасын үстерүгә зур өлеш кертә, ТР журналистлар кадрларын сыйфат ягыннан үстерүдә булышлык итә. 2004 тән ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары.

**РА́ТУША**, 18–19 йөзләрдә Россия шәһәрләрендәге үзидарә органы. Иң элек 1699 елда Бурмистр палатасы буларак оеша (шул вакытта ук Р. дип үзгәртелә). Башкала сәүдәгәрләре һәм һөнәрчеләренең җирле идарә органы булу б-н бергә, үзәк учреждение функцияләрен үти; Россия шәһәрләре халкының сәүдә-сәнәгать б-н шөгыльләнүче өлешеннән салым һәм һәртөрле җыемнар җыю ш.у. Р.га йөкләтелә. 18 йөз башында губерналар оештырылганнан соң, үзәк орган буларак әһәмиятен югалта; аның финанс функцияләре губерна учреждениеләренә тапшырыла. Сенатның 1728 ел 5 июль фәрманы б-н шәһәр *магистраты* Р. дип атала башлый (1743 тә магистратлар кабат тергезелә). 1775 тән Р.лар бистәләрдә генә оештырыла, алар губерна магистратларына буйсына, 3 елга сайлап куелган бургомистр һәм ратманнардан тора (халкы 500 кешедән ким булган бистәләрдә — 1 бургомистр һәм 2 ратман, эре бистәләрдә — 2 бургомистр һәм 4 ратман). Закон буенча Р.ның үз башлангычы б-н җинаять һәм гражданлык эшләрен карау вәкаләте булмый. Эш шәхси затлар шикаяте яки дәгъвасы, мәхкәмә, наместниклык идарәсе яки губерна магистраты күрсәтмәсе буенча гына ачыла. Р. карары б-н килешмәгән очракта, эш губерна магистратында карала. 1781 дә салымнар җыю, рекрут туплау, татарларны корабль төзелеше өчен урман кисәргә озату, Диния нәзарәтенә сайлаулар оештыру, бурычларны түләтү һ.б. б-н шөгыльләнүче *Казан шәһәре татар бистәләре ратушасы* оештырыла. 19 йөзнең беренче яртысында кайбер шәһәр һәм бистәләрдә адм.-хуҗалык һәм мәхкәмә учреждениеләре берләштерелә, шәһәрләрдә идарә эше, шәһәр думасы һәм магистратлардан алынып, Р.га йөкләтелә. 1839 да Казан губернасының 5 шәһәрендә шәһәр думасы һәм магистратлар Р. б-н алыштырыла. Р.лар 1866 да бетерелә.

*Әд.:* Дитятин И.И. Устройство и управление городов России: в 2 т. СПб., 1875–77.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**РАТУШНЯ́К** Анна Александровна (14.12.1946, Көньяк Казакъстан өлкәсе Чирчик ш., хәзер Үзбәкстан Респ-касы Ташкент өлкәсе), гидробиолог, биол. фән. д-ры (2002). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1970), Синтетик каучук фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1983 елдан ТР ФА каршындагы Экология проблемалары һәм җир асты байлыкларыннан файдалану ин-тында. Хезмәтләре аерым төр гидробионтларның токсиннар резистентлыгына сан ягыннан бәяләүнең методик нигезләрен эшләүгә карый. Р. гидробионтларның билгеле бер төре (Daphnia magna) буенча пиретроидлар мисалында ксенобиотикларның токсинлылык зоналарын ачыклау юлларын һәм планктон комплексы б-н үзара бәйләнеше исәбенә аның компенсациясен билгели.

Хезм.: Эффект действия малых и сверхмалых доз пиретроидов на Daphnia magna // Токсикол. вестн. 2000. № 2 (автордаш); Физиолого-биохимические особенности внешнего метаболизма макрофитов в сезонной динамике и его роль в формировании качества воды // Экол. химия. 2001. № 6 (автордаш); Влияние хлореллы (Chlorella vulgaris), прижизненных выделений рогоза узколистного (Typha angustifolia) на токсикорезистентность Daphnia magna // Токсикол. вестн. 2003. № 1 (автордаш).

**«РАУША́Н»**, язгы арпа сорты. 1995 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты б-н Кара туфраклы булмаган зоналарның үзәк р-ннары а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты һәм «Россия орлыклары» фәнни-җитештерү фирмасы б-н берлектә Э.Д.*Неттевич*, В.П.Смолин, Л.М.Ерошенко, Л.В.Денисова, Л.Г.Погорелова, Е.В.Кожемякин, В.И.Блохин тарафыннан икенче буын гибрид популяциясеннән аерым сайлап алып, соңыннан сынау юлы б-н чыгарыла. Куагының формасы тармаклану чорында җиргә сыланып җәелгән, тармаклануы яхшы. Башак астындагы яфрагында бик ачык күренмәгән антоциан төс бар. Кылчыклары очында шулай ук антоциан төс күзәтелә. Кылчыклары тешле, озын. Башагы цилиндрик формада, ике рәтле, озын. Бөртеге озынча, бөртек төбендәге кылы озын төкле. Уртача өлгерешле, вегетация чоры 73–82 көн. Биеклеге 58–73 *см*, сөрлегүгә уртача чыдам. Төрле типтагы туфракларда үсә. Югары һәм тотрыклы уңыш бирә. Иң югары уңыш — 1 *га* дан 75,6 *ц* Зәй дәүләт сорт участогында алына. 1000 бөртекнең авырлыгы 47–49 *г*, протеин 11–13% тәшкил итә. Бу сорт кулланылышы буенча универсаль, сыра ясау һәм бөртегенең сыйфаты буенча кыйммәтле сортлар исемлегенә кертелгән. Тузан гөмбәсе авыруыннан тотрыклылык гены б-н саклана, очкыл чык авыруына бирешми. 1998 дән бу сорт РФнең Үзәк, Идел-Вятка, Урта Идел регионнарында, ш.и. Татарстанда үстерергә рөхсәт ителә. 2007 дә респ-када 141 мең *га* мәйданда үстерелә.

*Әд.:* Руководство по апробации сортовых посевов. К., 2002.

**РА́ХЛИН** Леопольд Матвеевич (14.1.1898, Саратов ш. — 11.4.1994, Казан), кардиолог, мед. фән. д-ры (1927), проф. (1938), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1950, 1969). Профессорлар А.Р.Лурия, А.Ф.Самойлов, С.С.Зимницкий шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1922), Казан ГИДУВында, 1946–53 елларда — 2 нче терапия, 1953–74 тә 1 нче терапия каф. мөдире; бер үк вакытта, 1930–35 тә, ТАССР Эчке эшләр халык комис-тының мед.-сан. часте башлыгы. Тимерьюлчылар хастаханәсенең Казан бүлегендә 2 нче терапия кафедрасын оештыручы һәм аның мөдире (1936–56). 1934 елда челюскинчыларны коткару экспедициясе әгъзасы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1942–45 тә — Заполярьедагы 14 нче, 19 нчы армияләр, 1945–46 да Казан хәрби округы баш терапевты. 1971–85 тә Казан шәһәре сәламәтлек саклау идарәсенең махсус хастаханәсе консультанты. Хезмәтләре матдәләр алмашы бозылуны өйрәнүгә, электрокардиографиягә карый. СССРда электрокардиографияне гамәлгә кертүчеләрнең берсе, Казан ГИДУВының эчке аврулар клиникасында Идел буендагы беренче электрокардиография лаб-ясен оештыручы. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Электрокардиограмма при «компенсаторных» изменениях миокарда. К., 1936; Диагностическое значение серийных электрокардиограмм // Казан. мед. журн. 1940. № 3; О роли некоторых внутренних факторов в развитии атеросклероза // Казан. мед. журн. 1961. № 2; Пути электроимпульсной терапии мерцательной аритмии // Казан. мед. журн. 1972. № 6.

*Әд.:* Профессор Леопольд Матвеевич Рахлин // Кардиология. 1973. № 6.

**РА́ХЛИН** Натан Григорьевич (28.12.1905, Чернигов губ. Сновск ш. — 28.6.1979, Казан, Киевта җирләнә), оркестр дирижёры, педагог, Украина ССР, СССР, ТАССРның халык артисты (1947, 1948, 1972). 1913–15 елларда Чернигов музыка уч-щесендә укый. 1927 дә — Киев консерваториясен (Д.Бертье классы) скрипка классы буенча, 1930 да Н.Лысенко исем. Киев муз.-драма ин-тын (В.Бердяев һәм А.Орлов класслары) дирижёрлык буенча тәмамлый. 1931–35 тә Ленинград консерваториясендә М.Штейнбергта, читтән торып, музыка теориясен һәм композициясен өйрәнә. 1920 дән Кызыл Армия сафларында, Г.И.Котовский кавалерия бригадасында быргычы-сигналчы. 1922–26 да Киев югары хәрби мәктәбе оркестрында. 1930–34 тә Киев опера оркестры скрипкачысы, Самара музыка уч-щесе укытучысы; Харьков шәһәре радиоком-ты оркестры скрипкачысы һәм дирижёр ассистенты, консерватория укытучысы. 1934–37 дә Сталино шәһәрендә (хәзер Донецк ш.) үзе оештырган симф. оркестрның

баш дирижёры, 1937–41 һәм 1945–62 дә Украина ССР Дәүләт симф. оркестрның баш дирижёры. 1941–45 тә СССР Дәүләт симф. оркестры баш дирижёры. 1962 дән илнең бик күп симф. оркестрлары б-н, чакырылган дирижёр буларак, концерт эшчәнлеге алып бара. 1966 да Татар филармониясе симф. оркестрын оештыра (хәзер ТРның Дәүләт симф. оркестры), 1979 га кадәр аның сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижёры була. Бер үк вакытта, 1946–66 да — Киев консерваториясенең, 1967–75 тә Казан консерваториясенең оркестр б-н дирижёрлык итү классы профессоры. Укучылары арасында (Казанда эшләгән чорда) — В.М.*Васильев*, В.Н.Венедиктов.

Р. — 20 йөзнең иң күренекле дирижёрларыннан берсе. Аның уникаль дирижёрлык сәләтен, кабатланмас башкару стилен оркестрның сәнгати һәм техник мөмкинлеген тирән һәм һәрьяклап аңлавы, барлык оркестр уен кораллары б-н проф. эш итә белүе аерып тора. Көйне тоемлау һәм истә калдыру сәләте аңа кыска гына вакытта катлаулы партитураларны үзләштерү мөмкинлеген бирә.



Н.Г. Рахлин дирижёр пульты артында.

Р.ның башкару манерасына көчле темперамент, артистлык осталыгы, нәфис кул хәрәкәте, югары дәрәҗәдә камил дирижёрлык техникасы хас. Р. репертуары 1000 нән артык симф. әсәрне үз эченә ала; аның нигезен чит ил һәм рус классик, хәзерге украин һәм татар симф. музыкасы тәшкил итә. Дирижёр бигрәк тә романтик композиторлар музыкасын башкаручы интерпретатор буларак киң танылу ала. Л.Бетховен, Г.Берлиоз, Р.Вагнер, Ф.Лист, Г.Малер, П.Чайковский, С.Рахманинов, А.Скрябин, Н.Мясковский һ.б.ның симф. әсәрләренең барысын да диярлек башкара. Р.ның дирижёрлык осталыгы, артистлыгы, темпераменты И.С.Бахның «Чакона»сын (үзе оркестрга салган), Л. ван Бетховенның 9 нчы симфониясен, Г.Берлиозның «Фантастик симфония»сен, П.Чайковскийның 6 нчы симфониясен, «Манфред» симфониясен һәм «Франческа да Римини» фантазиясен, Д.Шостакович симфонияләрен (композиторның 11 нче симф. премьерасына дирижёрлык итә), Г.Свиридовның «Патетик оратория»сен башкарганда аеруча ачык күренә.

Р. татар симфониясе үсешенә зур өлеш кертә. Аның тарафыннан оештырылган коллектив СССР күләмендә иң яхшылардан була (1973 тә Бөтенроссия һәм 1977 дә Бөтенсоюз симф. оркестрлар конкурсы лауреаты). Р. җитәкчелегендәге гастрольләр СССРның күп шәһәрләрендә (Мәскәү, Ленинград, Сочи, Кисловодск һ.б.) уңышлы үтә. Дирижёр Татарстан композиторларының симф. иҗатына нигез салучы, Н.Җиһанов, Ф.Әхмәтов, А.Ключарёв, А.Луппов, Л.Любовский, Р.Белялов. һ.б.ның симфонияләрен, сюиталарын, концертларын беренче башкаручы була. Р. классик, ш.у. хәзерге композиторларның күп кенә партитураларының, ш.и. С.Сәйдәшев иҗат иткән «Совет Армиясе маршы»ның оригиналь редакцияләре авторы. 1 нче Бөтенсоюз дирижёрлар конкурсы лауреаты (1938). СССР Дәүләт премиясе (1952), Ленин ордены, Октябрь Рев-циясе ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Ялта шәһәрендә (Украина) 1998 дә Р.ның музей-йорты ачыла, АКШта 1999 дан Р. истәлегенә Мемориаль фонд эшләп килә. 2006 да Украина, АКШ һ.б. илләрдә концертлар, фестивальләр һәм истәлекле чаралар б-н Р.ның 100 еллыгы билгеләп үтелә; Казанда Р. исем. 1 нче Халыкара музыка фестивале оештырыла, 2011 дән даими рәвештә Халыкара «Рахлин сезоннары» фестивале уздырыла. Казанның бер урамы аның исемен йөртә.

*Әд.:* М а т у с е в и ч Н. Натан Григорьевич Рахлин — народный артист СССР. Киев, 1960; Натан Рахлин: Статьи. Интервью. Воспоминания. М., 1990; Натан Рахлин: Материалы, статьи, воспоминания, интервью. К., 2006.

*Г.М.Кантор.*

**РАХМА́Н** (псевд., Рахмани) Равил Фәйзерахман улы (8.5.1949, Буа р-ны Адав-Толымбай а.), әдәбият галиме, шагыйрь, филол. фән. канд. (1985), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1999). Казан ун-тын тәмамлый (1971). 1974 елдан (бүленеп) Татарстан китап нәшриятында. 2002–05 тә ТРның РФдәге вәкиллегендә, 2007 дән ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында (2007–12 дә әдәбият белеме бүлеге мөдире). Хезмәтләре татар әдәбияты теориясе һәм тарихына карый. «Татар балалар поэзиясе антологиясе» (1980), «Әдипләребез» (Р.Даутов б-н берлектә, 1–2 т., 2009) биобиблиогр. белешмәлеге, ш.у. «Татар әдәбияты тарихы» (8 томда; 1–2 т. — 2014; 3 т. — 2015; 4 т. — 2016) проектлары авторларының, төзүчеләренең берсе һәм җаваплы мөхәррире.

Ә с ә р.: Шигъри бишек. К., 1981; Канатлы дөнья. К., 1984; Мең чакрымга мең чакрым. К., 2006.

*Әд.:* В ә л и М. Гасырлар ярында... // Казан утлары. 1999. № 5; Ю н ы с М. Чакрымнарын югалткан мең чакрым... // Казан утлары. 2009. № 5.

**РАХМА́Н** (Габдрахманов) Хәбра (Хәбибрахман) Габдрахман улы (1914, Вятка губ., Малмыж өязе Янгул а. — ноябрь 1942, Калинин өлкәсе Максатиха тимер юл станциясе), шагыйрь. 1936 елда Казан пед. ин-тын тәмамлый. Алабуга пед. уч-щесендә укыта. Бөек Ватан сугышында катнаша. Мәскәү өчен барган сугышларда яралана, госпитальдә вафат була. Очерклар, «Чәчәк ява» (1937) шигырьләр җыентыгы, тәмамланмаган «Шомырт чәчәкләре» повесте авторы.

*Әд.:* Алар сафта. К., 1961.

**РАХМАНГУ́ЛОВ** Зәки Салават улы (5.6.1923, Оренбург өлкәсенең Куандык р-ны Бозаулык а. – 28.7.2009, Медногорск ш.), горновой, төсле металлар эретүче, Соц. Хезмәт Герое (1966). Медногорск һөнәр уч-щесен тәмамлый (1942). 1948–49 елларда һөнәр уч-щесендә производствога өйрәтү мастеры; 1949–73 тә «Медногорск бакыр-күкерт комбинаты» ҖЧҖдә (Оренбург өлкәсе) горновой, өлкән горновой, 1973–94 тә слесарь-сантехник, 1994–97 дә кладовщик. Герой исеме төсле металлургиядә ирешкән уңышлары өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Медногорск шәһәренең мактаулы гражданы (1979).



Н.Г. Рахлин.



З.С. Рахмангулов.

*Әд.:* А л ь т о в В. Медногорск. Челябинск, 1989; Р о с с о в с к и й В.П. Герои Труда: Биогр. справ. Калуга, 1999; Металлурги Урала: Энцикл. Екатеринбург, 2001.

**РАХМАНКО́ЛОВ** (Рахманколый) Әхмәт (Шаһиәхмәт) Таҗетдин улы (1886, Оренбург губ. Троицк ш. — 1939 дан соң), драматург. Троицкида атасы мәдрәсәсендә («Рахманколый»), аннары Бохарада, Истанбулда укый, елга якын Троицкида рус телен өйрәнә. 1911 елдан тегермәндә идарәче булып эшли, сәүдә б-н шөгыльләнә. 1914 тән Төркиядә сәүдәгәр Яушевның сәүдә йорты вәкиле була; татар студентларының иҗтимагый хәрәкәтендә, «Тәгареф әл-Ислам» г-тасын чыгаруда катнаша. Троицкига кайткач, 1917 нең мартында «Хөр милләт» г-тасын редакцияли, 1920–22 дә укыту эшендә. 1925–32 дә Казанда, соңрак Урта Азиядә. «Чыңгызхан» (Истанбул, 1914), «Упкын» (1925), «Боз астында дулкын» (1926; 2 басма 1992), «Җиһан тетрәгәндә» (1926), «Кара күләгәләр» (1931) һ.б. татар һәм рус театрларында куелган пьесалар авторы. 1929 да «Востоккино» студиясендә Р.ның «Упкын» пьесасы буенча «Комета» фильмы төшерелә (реж. В.Инкинижов). 1938 дә репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.


*Әд.:* С а ф и у л л и н Ю. Атылган йолдыз // Идел. 2000. № 9; Татар драматурглары: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2007.

**РАХМАНКОЛЫ́Й** Габденнасыйр (? — 1835, Казан), дин эшлеклесе. Каргалы мәдрәсәсендә белем ала (Оренбург өлкәсе). 1825 тән Зәңгәр мәчетнең имам-хатибы (Казан). Казандагы иң беренче мәдрәсәләрнең берсенә — «Халидия»гә нигез салган шәхес (1825).

*Әд.:* С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Исторические мечети Казани. К., 2005.

**РАХМАНКОЛЫ́Й** (Рахманкулов) Солтан (Әхмәтсолтан) Габделмәннан улы (1888, Казан губ. Олы Шыңар а. — 8.4.1916, Казан), язучы, тәрҗемәче, тел галиме. Казанда 1 нче реаль уч-щедә укый, 1905 елда студентлар





Г.Г.Р а х м а н к у л о в а. 1. «Казанда яз». 1961. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. «Казан Кремленең Спас манарасы». Акварель. 1967; 3. «А́лла». 1960 еллар.

чуалышларында катнашканы өчен аннан куыла. 1908 дән «Йолдыз» г-тасы редакциясендә эшли, шунда үзенең беренче хикәяләрен бастыра. Соңыннан алар «Мәлиха куаклыгы» (1918) җыентыгына керәләр (1979 да М.Мәһдиев кабат бастыра). 20 йөз башында татар матбугатында Р.ның публицистик мәкаләләре һәм тәрҗемәләре актив басыла. Татар теленә А.С.Пушкин, Л.Н.Толстой, И.С.Тургенев, М.Горький, В.Гюго әсәрләрен, фәнни-популяр брошюралар тәрҗемә итә. Мәктәп һәм мәдрәсәләр өчен «Русча-татарча кесә лөгате» (1915), русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр һәм уку ярдәмлекләре авторы.

*Әд.:* Татар әдипләре һәм мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиогр. сүзлек. К., 2005; Г а й н у л л и н М. Татарская литература и публицистика начала XX века. К., 1983.

*А.М.Ахунов.*

**РАХМАНКУ́ЛОВ** Илгиз Шамил улы (23.8.1941, Уфа — 21.1.2017, Казан), икътисадчы, радиоинженер, икътисад фән. д-ры (1990), проф. (1993). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1965). 1959–79 елларда (бүленеп) Казан Электрон-хисаплау машиналары (ЭВМ) з-дында: инженер, цех башлыгы (1970–71), директор урынбасары — з-дның махсус КБ башлыгы; ВЛКСМның — Казан шәһәр (1971–72), Татарстан өлкә ком-ты (1972–75) 1 нче секретаре. 1979–93 тә ТАССР Элемтә җитештерү-техник идарәсе (1991 дән — «Связьинформ» элемтә һәм информатика дәүләт пр-тиесе) башлыгы. 1993 тән Казан финанс-икътисад ин-тының җитештерү икътисады каф. профессоры. Хезмәтләре икътисади-матем. модельләштерү һәм фаразлау, катлаулы техник системаларның, ш.и. телекоммуникация системаларының сыйфатын һәм ышанычлылыгын идарә итү проблемаларына карый. 1991–93 тә Технол. фән. академиясенең Татарстан төбәк бүлеге президенты. 1973–80 дә ТАССР ЮС депутаты, 1975–80 дә — ТАССР ЮС президиумы, 1971–75 тә ВЛКСМ ҮК әгъзасы. Халыклар дуслыгы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Категория «средняя величина» и её методологическое значение в научном исследовании. К., 1982 (автордаш); Многомерный статистический анализ качества и надёжности функционирования сложных технических систем (СТС). К., 1984.

**РАХМАНКУ́ЛОВА** Гайшә Габдрахман кызы (3.12.1913, Уфа губ., Уфа өязе Кырмыскалы а. — 3.5.1991, Казан), нәкышьче, график, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1974), ТАССРның халык рәссамы (1984). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1942). Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый (1941). 1942 елдан Татарстан сәнгать фондында (1953 кә кадәр — «Татхудожник») эшли. Беренче татар хатын-кыз рәссамнарыннан. Күп кенә станлы нәкышь жанрларында актив эшли: портрет («Әни портреты», 1946; «ТАССРның халык артисткасы Галия Кайбицкая Алтынчәч ролендә», 1947), көнкүреш («Яшь натуралистлар», 1950; «Студентлар», 1952), пейзаж («Ташу», 1953; «Ленин бакчасында», 1954; «Шәһәрдә яз», 1954), натюрморт («Пионнар», 1955). Әйдәп баручы акварель остасы. 1976 га кадәр хезмәтләре бөтенсоюз акварель күргәзмәләренә куелган бердәнбер татар рәссамы була (1972, 1975). Төп әсәрләре: «Алмагачлар чәчәк ата», «Көз», «Кечкенә ишегалды», «Шат күңелле хатын», «Казанның яңа районы» (1957–60). Европа буйлап сәяхәт иткәннән соң, Греция, Төркия, Италия, Франция, Англия, Дания, Урта диңгез, Атлантик океан күренешләре кергән зур цикл акварель рәсемнәр иҗат итә. Соңрак, Идел һәм Төньяк Кавказ буйлап сәяхәтенә бәйле, шәхси үзенчәлекләре, төсләр тулылыгын ачу сәләте, дөньяны күрә белү киңлеге ачылган цикллары барлыкка килә. 1960–70 елларда Казан образы аның иҗатында үзәк урыннарның берсен алып тора: борынгы һәйкәлләр һәм яңа кварталлар, зур шәһәрнең кайнап торган тормышы гәүдәләнә («Казан Кремленең Спас манарасы», 1967; «Аргы Кабан», 1968; «Балалар дөньясы», 1974). 1980 елларда Р. Татар акад. театры артистларының портретлары сериясен иҗат итә («РСФСРның халык артисткасы В.Минкина Т.Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» пьесасы буенча куелган спектакльдә М.Җәлилнең әнисе ролендә»; «РСФСРның халык артисты Венера Шәрипова» һ.б.). Респ-ка (1944 тән) һәм төбәк (6 автономияле респ-ка рәссамнарының хезмәтләре күргәзмәсе, Казан, 1947; Идел буе, Әстерхан рәссамнарының өлкә күргәзмәсе, 1956; «Зур Идел», 1967–91), бөтенроссия «РСФСРдагы автономияле республикалар рәссамнары», Мәскәү, 1971) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда уздырыла (1963, 1969, 1974, 1981, 1988, 1993, 1997, 2003).



«Г.Г. Рахманкулова портреты». Рәссам З.Ф. Гыймаев. 1991. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, А.М.Горький әдәби-мемориаль музеенда (Казан), Әлмәттәге картиналар галереясында саклана.

*Әд.:* Изобразительное искусство Советского Татарстана. К., 1957; Выставка акварельных работ художника Гайши Абдрахмановны Рахманкуловой: Каталог. К., 1964; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

**РАХМАНКУ́ЛОВА** Йөзем-Өрек Салих кызы (14.9.1925, Симферополь ш.), тел галиме, филол. фән. д-ры (1976), проф. (1978), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1994). Совет Армиясенең чит телләр хәрби ин-тын тәмамлаганнан соң (Мәскәү, 1950), шунда ук эшли. 1956 дан Бөтенсоюз азык-төлек сәнәгате читтән торып уку ин-тында (Мәскәү), 1960 тан Мәскәү электрон машина төзелеше ин-тында, чит телләр каф. мөдире; 1976 дан СССР Тышкы эшләр министрлыгының Мәскәү халыкара мөнәсәбәтләр ин-тында, немец теле һәм Скандинавия телләре каф. мөдире; 1979 дан Мәскәү өлкә пед. ин-тында, немец теле каф. мөдире; 1996 дан Мәскәү шәһәр пед. ун-тында. Хезмәтләре немец теленең функциональ грамматикасына, телләрнең чагыштырма типологиясенә, чит телләр укыту методикасына карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Интенсивная грамматика немецкого языка. М., 1993; Практика функционального немецкого языка. М., 2005.

**РАХМАНКУ́ЛОВА** Мәрьям Габделмәннан кызы (20.11.1901, Казан — 8.2.1990, шунда ук), җырчы (меццо-сопрано), композитор, фольклорчы, ТАССРның һәм РСФСРның

халык артисты (1944, 1957). Композиторлар берлеге әгъзасы (1940). 1929 елда Казан шәрекъ музыка техникумын вокал буенча (Е.*Ковелькова* классы) тәмамлый. 1928–34 тә Татарстан радиосы солисты һәм муз. редакторы була. Бу чорда Р. Татарстан композиторларының әсәрләрен һәм татар халык җырларын пропагандалауга зур өлеш кертә, яшь башкаручыларны концерт эшчәнлегенә җәлеп итәргә, респ-када муз.-агарту эшен үстерүгә булыша. 1930 да Мәскәүдә Милли театрлар олимпиадасында катнаша, анда үзенең беренче грампластинкасын яздыра. 1934–38 дә Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә вокал (Е.Петренко классы) һәм композиция буенча (Г.Литинский классы) укый. 1939–60 та Татар опера һәм балет театры солисты. Европа һәм рус классик опералары репертуарындагы төп меццо-сопрано партияләрен: Азучена («Трубадур», Дж.Верди), Кармен (шул исем. опера, Ж.Бизе), Няня, Графиня, Любовь («Евгений Онегин», «Пики дамасы», «Мазепа», П.Чайковский) һ.б.ны башкара. Татар композиторларының опералары һәм муз. комедияләрендәге Тугзак, Сабира, Әминә («Алтынчәч», «Илдар», «Намус», Н.Җиһанов), Бәдига («Галиябану», М.Мозаффаров), Җиһан («Башмагым», Җ.Фәйзи) һ.б. партияләрне беренче башкаручы. Опера сәхнәсендә истә калырлык төрледән-төрле образлар (трагик образлардан алып комик образларга кадәр) галереясын тудыра. Актив концерт эшчәнлеге алып бара. Җырчының зур һәм төрле пландагы концерт репертуары Көнбатыш Европа, рус һәм совет композиторларының вокаль әсәрләрен, революцион һәм халык җырларын үз эченә ала. Р. татар халык җырларын (бигрәк тә борынгы көйләрне), Татарстан композиторларының вокаль музыкасын үтә нечкә интерпретацияләве б-н аеруча танылды. Җырчы буларак, Р.ның үзенчәлекле иҗади йөзе милли вокаль башкару үзгәлеге һәм акад. җырлау осталыгы б-н аерылып тора. Аның тавышына диапазон киңлеге, яңгыраш күләме, йомшак һәм колоритлы тембр хас. Башкаручы эчке кичерешләрне һәм әсәрнең эчтәлеген төгәл бирә, төрле төсмерләрне чагылдыра ала. Симф. оркестр өчен әсәрләр, җырлар, драматик спектакльләргә, радиоспектакльләргә музыка, татар һәм башкорт халык җырларына эшкәртмәләр авторы. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



М.Г. Рахманкулова.

*Әд.:* Мәрьям Рахманкулова җырлый. К., 1984. Народные артисты. К., 1980; Хайруллина З.Ш. Марьям Рахманкулова // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986.






М.Г. Рахманкулова: 1. Тугзак («Алтынчәч», Н. Җиһанов); 2. Яз («Кар кызы», Н. Римский-Корсаков); 3. Җиһан («Башмагым», Җ. Фәйзи) рольләрендә.

**РАХМА́НОВ** Рәфкать Мәҗит улы (15.3.1948, Әлмәт р-ны Нәдер а.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009), ТРның атказ. нефтьчесе (1993), РФнең атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре (1998). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1970), «Татнефть» АҖдә эшли (бүленеп): район инженер-технол. хезмәте (1976 дан), «Җәлилнефть» НГДУында җитештерү бүлеге (1978 дән), Нефть промыселы җиһазларын ремонтлау буенча Әлмәт җитештерү хезмәте күрсәтүнең үзәк базасы (1986 дан) башлыгы, ятмаларның нефть бирүчәнлеген арттыру һәм скважиналарны ремонтлау буенча ген. директор урынбасары (2001 дән). 1972–82 дә «Мострансгаз» ҖБдә. Уйлап табуга 20 патенты бар. Дәүләт бүләге нефть чыгару скважиналарының нәтиҗәлелеген күтәрү һәм яңарту, саклау өчен техник һәм технологик мәсьәләләр комплексын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**РӘВА́Җ** (Rheum), карабодайчалар семьялыгыннан үсемлекләр ыругы; күпьеллык үләнчел үсемлек, итләч, көчле тамырлы, бик эре тамыр яны яфраклары тоташ розетка барлыкка китерәләр, яфрак сабаклары озын, итләч, сусыл. Чәчәк сабагы тоташ яисә куышлы, биеклеге 1,5–2 *м*. Чәчәк оешмасы себеркәчле яисә башаксыман. Чәчәкләре ике җенесле, кайвакыт ата җенеслеләр генә очрый. Җимеше — өчкырлы, коңгырт канатлы орлык. 30 төре билгеле, дару һәм яшелчә төрләре күп файдаланыла. Чыгышы б-н Көнчыгыш Азиядән. Татарстанда бакча культурасы, яшелчә һәм дару үсемлеге буларак үстерелә. Р. тамырын аеру юлы б-н һәм орлыктан үрчетелә. Туклану мәйданы 1х1 *м*. Уңышы утыртканнан соң икенче елда май башыннан июньнең беренче декадасына кадәр җыела. Бер урында 10–15 ел үсә, ел саен 1 $м^2$ дан 3–6 *кг* (1 *га* дан 30–60 *т*) яфрак сабагы бирә, алардан кесәл, компот, кайнатма әзерләнә. Иртә язда яфраклары «яшел» ашти пешерү өчен кулланыла. Сортлары: «Виктория», «Московский 42», «Крупночерешковый», «Огарский 13», «Тумутукский 5».



**РӘВЕ́Ш**, эш, хәл, билгеләрнең, сирәгрәк предмет һәм затларның процесска бәйле булмаган билгеләрен белдерүче сүз төркеме. Процесска бәйле булмаган билгеләр дигәндә, эш, хәл һәм билгеләрнең сыйфатын (**акрын** бару, **тиз** кайту), күләмен һәм дәрәҗәсен (**озак** көтү, **шактый** зур), урынын (**түбән** төшү, **югары** менү), вакытын (**иртән** китү, **кич** кайту), сәбәбен һәм максатын (**юкка** борчылу, **юри** эшләү) күздә тоталар. Үзенең гомуми лексик-грамматик мәгънәләре — процесска бәйле булмаган билге белдерүләре б-н Р., башка телләрдәге кебек үк, сыйфатка якын тора. Морфологик яктан Р., сыйфат кебек үк, грамматик яктан формалашмаган. Ул — төрләнми торган сүз төркеме. Р.ләрнең бер өлеше генә чагыштыру һәм артыклык дәрәҗәләрендә килә ала (ерак — ераграк, көндез — көпә-көндез).

Синтаксик яктан Р. күбрәк фигыльне (**җәяү** бару), сыйфатны (**бик** кызыклы) яки башка бер рәвешне (**бераз** китапча), кайбер очракларда исемне дә (**татарча** көрәш) ачыклап килә. Җөмләдә, нигездә, хәл функциясен үти, аерым очракларда аергыч һәм хәбәр дә булып килә. Лексик-грамматик мәгънәләре ягыннан Р.не билге һәм хәл Р.ләренә аерып карыйлар. Билге Р.ләре эш-хәл яки билгенең сыйфатын, үтәлү рәвешен, күләм-чамасын, микъдарын белдерәләр, шуннан чыгып үз эчендә тагын 2 төркемчәгә бүленәләр: 1) эш-хәлнең үтәлү рәвешен белдергән Р.ләр: тиз, җәяү, төрлечә, өчәүләп һ.б.; 2) күләм-чама Р.ләре, алар эш-хәл һәм билгенең билгеле һәм билгесез санын, ш.у. күләм-чамасын белдерәләр: бик, аз, өлешчә, көне-төне һ.б. Хәл Р.ләре эш-хәлнең үтәлү вакытын, урынын, сәбәбен, максатын белдерәләр һәм түбәндәге төркемчәләргә бүленәләр: 1) урын Р.ләре: ерак, якын, янәшә, югары; 2) вакыт Р.ләре: хәзер, иртәгә, быел, иртән, көндез; 3) сәбәп-максат Р.ләре: юри, юкка, бушка, заяга, тиктомалга һ.б.

*Әд.:* Татар грамматикасы. Морфология. М.–К., 2002. Т. 2; Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006; Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006.



С.С. Рәинбәков.

**РӘДИ́Ф** (гарәп. ردیف — җайдак артында утырып баручы), шәрекъ халыкларында поэтика термины; шигъри юлның ахырында, рифма артыннан (сирәк очракта алдыннан), үзгәртелмичә кабатланып килә торган сүз (кыска Р.) яки сүзләр төркеме (киңәйтелгән Р.) Гарәп, фарсы, төрки поэзияләрдә шигырьнең интонацион яңгырашын, музыкальлеген көчәйтү өчен поэтик фигура буларак кулланыла. Газәл, касыйдә, робагый жанрларында очрый: «Инкисар ит гадәтеңчә, ян, күңел, сызлан, **күңел**! Күп сөекледер бөтеннән — Тәңрегә сынган **күңел**!» (Г.Тукай).

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; К в я т к о в с к и й А. Поэтический словарь. М., 1966.

**РӘДҮДИ́** Гобәйдулла Габделмөэмин улы (1885, хәзер Оренбург өлкәсе, Сакмар р-ны Рәдүт а. — 28.11.1912, шунда ук), шагыйрь. Укытучы булып эшли. «Кыйссалы вә хиссалы шигырьләр» (1907), «Гөлзаре сыйбиян» («Балаларга чәчәк түтәле», Оренбург, 1907), «Мәктәп өчен шигырьләр» (Оренбург, 1909) исемле шигъри җыентыклар авторы. Аерым шигырьләре «Дин вә мәгыйшәт», «Шура» ж-лларында, «Бәянелхак» һ.б. г-таларда басыла. «Табигатькә сәяхәт, яки тарихы табигыйә» (Оренбург, 1908), «Тәсһиле җәгърафия» («Җиңел аңлаешлы география», Оренбург, 1911) дәреслекләре авторы.

*Әд.:* Г и л а з е в З.З. Татарская литература начала XX века в книжных изданиях. К., 2005.

**РӘҖӘ́ПОВ** Абдулла (Габдулла) Арифулла улы (1897, Сембер губ., Корсун өязе Гурьевка пос. — 10.4.1921, Мәскәү), Кызыл Армия командиры. Эшче-крәстияннәр Кызыл Армиясе Генштабы академиясендә укый (1920 елның сентябреннән). 1916 да Россия армиясенә чакырыла һәм һавада җиңел аппаратларда очу отрядына алына. Прапорщиклар мәктәбен тәмамлый. 1917 елгы Февраль рев-циясендә (Петроград) катнаша. 1917 нең җәендә сугышка җибәрелә, Барановичи шәһәре тирәсендәге (Белоруссия) һава сугышында аның самолёты бәреп төшерелә. 1917 нең ноябрендә, госпитальдә дәваланганнан соң, Гурьевкага кайта, Совет хакимиятен урнаштыру агитациясе алып бара. Сембер һәм Саратов губерналарында Кызыл гвардия отрядларын оештыруда катнаша. Сембер губернасының Корсун өяз советы әгъзасы; Кузнецк рев-ция ком-ты рәисе, Саратов губернасының Сызрань гарнизоны башлыгы. Гражданнар сугышында катнаша, 1918 дә Көнчыгыш фронтның 1 нче армиясендә батальон командиры, Төркестанда интернациональ полк командиры. 1919 да Ташкентта совет хакимиятенә каршы фетнәне бастыруда катнаша. 1919 ның язында Идел буе татар укчыларының икенче аерым бригадасын оештыруда катнаша, шул бригаданың командиры. Генштаб Академиясендә укыган вакытта каты авырудан үлә.

*Әд.:* М у л ю к о в М. Резепов Абдулла Арифуллович // Борцы за счастье народное. К., 1988. Кн. 3; Г р и ш и н Я.Я., Ш а р а ф у т д и н о в Д.Р. На службе Родине. К., 2005.

**РӘҖӘ́ПОВ** Әнвәр Закир улы (20.6.1942, Үзбәкстан ССРның Сәмәрканд өлкәсе Галләарал р-ны Милютино ст.), физик, техник фән. д-ры (1996), проф. (2001). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1965), ГИПОда эшли. 1973 елдан Мәскәүдә: Әйләнә-тирәне тикшерү экология-мәгълүмат системалары фәнни-тикшеренү ин-тында (1977–84), Бөтенсоюз электротехника ин-тында (1984–89), Кыйммәтле металлар һәм алмазлар фәнни-тикшеренү һәм проектлаштыру ин-тында (1989–94), Мәскәүнең Табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирәне саклау департаментында (1994–2007), Мәскәү корыч һәм эретмәләр ин-тында, җылылык физикасы һәм экология каф. профессоры (2007 дән), Бөтенроссия химик реактивлар һәм аеруча саф химик матдәләр фәнни-тикшеренү ин-тында, бер үк вакытта Җир төзелеше ун-тында (2012 дән). Хезмәтләре әйләнә-тирәнең пычрануларын тикшерү алымнарын һәм аппаратлар системасын эшләүгә карый. Уйлап табуга 22 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Мобильные лаборатории контроля атмосферных загрязнений и промышленных выбросов // Экология и промышленность России. 2009. № 6 (автордаш); Методы контроля и системы мониторинга загрязнений окружающей среды. М., 2011; Эколого-экономические аспекты системы управления природопользованием территорий регионального уровня // Экономика природопользования. 2012. № 1 (автордаш).

**РӘҖӘ́ПОВЛАР**, татар морзалары нәселе. Мишәрләр катлавыннан. 19 йөзнең 2 нче чирегендә кантон түрәләре (чиновниклары) буларак нәселдән күчмә дворянлыкка лаек булалар һәм Оренбург губернасы дворяннары шәҗәрә китабының 3 нче кисәгенә кертеләләр (1850 елның 12 декабрендә Сенат тарафыннан раслана). Нәсел башлыгы — 2 нче һәм 3 нче мишәр кантоннары идарәчесе, йөзбашы Фәзлулла Зәмгур улы Р.; 4 нче дәрәҗә Изге Станислав ордены б-н бүләкләнә (1835). Аның улы, хорунжий Шаһибәк Р. (1812–?) 2 нче мишәр кантоны башлыгы, Оренбург губернасының Эстәрлетамак өязе Бозаяз авылында яши.

*Әд.:* Н о в и к о в В.А. Сборник материалов для истории уфимского дворянства. Уфа, 1870; Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*Р.Х.Әхмәтҗанов.*

**РӘЙ́МОВА** Сания Исхак кызы (30.6.1937, Казан), музыка белгече, педагог, пед. фән. канд. (1973), проф. (1994), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1988). Казан консерваториясен тәмамлаганнан соң (1961), Кызыл (Тува) шәһәре музыка уч-щесендә, 1962 елдан Ташкент консерваториясендә укытучы булып эшли. 1968 дән Казан пед. ин-тында, музыка теориясе, тарихы һәм музыка уен кораллары каф. мөдире (1977–97). Мәктәп укучыларына эстетик тәрбия бирүгә, музыка укытучыларының белемен күтәрүгә, татар муз. культурасы тарихына багышланган 60 тан артык хезмәт авторы. Берничә ел рәттән «Татарстан» ДТРКның Казан телевидение студиясендә «Музыка тарихы сәхифәләре» тапшырулар циклын алып бара.

Х е з м.: История татарской музыки: Учеб. пособие. К., 1986; Татарская музыка на уроках сольфеджио: Учеб. К., 1993.

*Әд.:* К а н т о р Г.М. Музыковеды Казани: Биобиблиогр. словарь. К., 2000.

**РӘИНБӘ́КОВ** Сәет Садыйк улы (11.5.1948, Ямал-Ненец автономияле округының Яр-Сале пос.), җырчы (бас), ТРның халык артисты (1996). Казан консерваториясен вокал буенча (В.Лазько классы) тәмамлый. 1976–2000 елларда Татар опера һәм балет театры солисты. 2006–2011 дә Казанның Актёрлар йорты директоры, бер үк вакытта концерт эшчәнлеген дәвам итә. Төп партияләре: Дон Базилио («Севилья чәчтарашы», Дж.Россини), Даланд («Очучы голланд», Р.Вагнер), Мефистофель («Фауст», Ш.Гуно), Цунига



С.С. Р ә и н б ә к о в Цунига ролендә («Кармен» операсы, Ж. Бизе).

(«Кармен», Ж.Бизе), Тегерменче («Русалка», А.Даргомыжский), Варлаам («Борис Годунов», М.Мусоргский), Бораш, Журавлёв («Алтынчәч», «Җәлил», Н.Җиһанов), Җиһангир (шул исем. опера, Р.Гобәйдуллин), Фәхри («Кара йөзләр», Б.Мөлеков), Тимерхан («Еректагы кәккүк тавышы», Р.Кәлимуллин) һ.б. Татар композиторларының вокаль музыкасын пропагандалауга аеруча зур игътибар бирә. Бөтенроссия совет җырлары конкурсы лауреаты (1978, Сочи ш.).

**РӘЙХА́Н** (Ocimum), иренчәчәклеләр семьялыгыннан берьеллык үләннәр һәм ярымкуаклар ыругы. 150 гә якын төре билгеле. Чыгышы — Африка, Азия, Американың тропик һәм субтропик өлкәләреннән. Сабагы туры, дүрт кырлы, ботаклы, 60 *см* га кадәр биеклектә. Яфраклары каршыдаш, озынча түгәрәк. Чәчәкләре ак, аксыл-алсу яки аксыл-шәмәхә төстә, чәчәк сапларында, сабак очындагы яфрак куентыгында урнашкан. ТР терр-ясендә кайбер төрләре — затлы Р. (O.basilikum), эвгеноль Р.ы (O.gratissimum) — декоратив һәм хуш исле үсемлек буларак үстерелә. Орлыктан үрчетелә. Җылы һәм яктылык яратучан үсемлек. Сабагы, яфраклары һәм чәчәкләре

медицинада, парфюмериядә, азык сәнәгатендә (ванилин алу өчен), ш.у. тәмләткеч буларак кулланыла.

**РӘКЫ́ЕВА** Мөстәнфирә Таһир кызы (24.11.1927, Буа кантоны Кул Черкене а.), анатом, мед. фән. д-ры (1972), проф. (1974). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), шунда ук, нормаль анатомия кафедрасында эшли. 1973 елдан Барнаул мед. ин-тында нормаль анатомия каф. мөдире. Хезмәтләре кан юллары анатомиясенә, арка миенең кан б-н тәэмин ителеше мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Тонкая васкуляризация узлов симпатического ствола некоторых животных и человека. К., 1955.

**РӘКЫЙБИ́** (Габделрәкыйбов) Рәкыйб Кәрим улы (1887, Оренбург губ. Каргалы а. — 1963, башка мәгълүматлар буенча 1967, Ташкент), тәрҗемәче, журналист. «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый, 1905 елда революцион хәрәкәттә катнашканы өчен аннан куыла. 1906–10 да «Казан мөхбире», «Бәянелхак» (Казан), «Вакыт» (Оренбург) г-талары хезмәткәре. 1910–19 да хәрби хезмәттә, Гражданнар сугышында катнаша. 1919 дан партия эшендә (Минск, Севастополь, Феодосия, Чимкент һ.б. шәһәрләрдә). 1930 елларда Каракалпак автономияле өлкәсенең Төрткүл шәһәрендә пед. техникумы директоры булып эшли, соңрак Нукус шәһәренә күчә, анда җирле газета чыгаруны оештыра һәм аны 1950 гә кадәр җитәкли. Татар теленә Л.Н.Андреев, В.М.Гаршин әсәрләрен, Гөлнар ханымның (О.С.Лебедева) «Мөслимәләр хөррияте» («Об эмансипации мусульманских женщин», СПб., 1900) исемле хезмәтен, социал-демократик эчтәлекле брошюралар тәрҗемә итә.

*Әд.:* Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (ХХ йөз башы): Биобиблиографик сүзлек. К., 2005.

**РӘКЫ́ЙПОВ** Роберт Җиһанша улы (10.11.1936, Чүпрәле р-ны Яңа Чокалы а. — 4.5.1995, Әлмәт ш.), шагыйрь. Казан ун-тының физика-матем. ф-тын тәмамлый (1970). 1969–74 елларда Чүпрәле р-ны мәктәпләрендә укытучы, соңрак мәктәп директоры булып эшли. 1974 тән Әлмәттә яшь һәм интернат-мәктәптә физика, математика укыта. «Сагыну» (1981), «Сиңа гына ачам күңелемне» (1983), «Яшьлегем башкаласы» (1985), «Җилкәннәрдә зәңгәр җилләр» (1986), «Хәтер урамы» (1988) шигырь җыентыклары авторы. Иҗатында диңгез тематикасы, туган җиргә мәхәббәт зур урын алып тора. Р. шигыренә язылган «Мин яратам сине, Татарстан!» (Р.Андреев көе) җыры 2008 дә Г.Тукай исем. ТР Дәүләт бүләгенә лаек була.

**РӘКЫ́ЙПОВ** Шамил Җиһанша улы (22.9.1929, Буа кантоны Яңа Чокалы а. — 17.2.2005, Казан), язучы, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1980). Казан ун-тын тәмамлый (1967). Туган авылында колхозда эшли. 1950 елда, колхоз амбарында эшләгәндә, авылдашларына ашлык бүлеп биргәне өчен аны җаваплылыкка тарталар һәм, 10 елга хөкем итеп, Себергә мәҗбүри хезмәт колониясенә җибәрәләр; 1954 тә амнистиягә эләгеп кире кайта. 1955 тән Казанда. 1957 дән «Татарстан яшьләре» г-тасында: әдәби хезмәткәр, тәрҗемәче, бүлек мөдире. 1966 дан Татарстан китап нәшриятының яшүсмерләр-балалар редакциясе бүлеге мөдире. 1993–2000 дә «Шәһри Казан» г-тасында әдәби хезмәткәр. Иҗатының башлангыч чорында Р. скетчлар, хикәя, очерклар, лирик парчалар яза («Сөю билгесе», 1959; «Тынгысыз яшьлек», 1963 җыентыклары). 1960 еллар уртасыннан иҗатында төп урынны Бөек Ватан сугышы темасы алып тора. Татар әдәбиятында документаль проза тармагының ныгуына, сәнгати яктан баюына үзеннән зур өлеш кертә. Әдип архивларда эзләнә, сугыш булган урыннарга бара, элекке фронтовиклар б-н очрашып сөйләшә. Шул бай материалларга таянып, үзенең «Геройлар үлмиләр» (1978), «Аяз күктә карлыгачлар» (1982) исемле очерк җыентыкларын, Советлар Союзы Геройлары Бари Шәвәлиев, Гыйльфан Батыршин, Иван Кабушкин турында «Чәчәкләр сөйли белә»(1967; русчага тәрҗемәсе «О чём говорят цветы?», 1971), «Таңнар һаман матурмы?» (1970; русчага тәрҗемәсе «Прекрасны ли зори?», 1973), «Кайдан син, Жан?» (1969; русчага тәрҗемәсе «Откуда ты, Жан?», 1974) повестьларын, очучылар Мәгубә Сыртланова һәм Ольга Санфирова турында «Кызлар-йолдызлар» (1973; русчага тәрҗемәсе «Звёдные ночи», 1983) һәм «Кипарислар җыры» (1976), генерал В.Гордовның фаҗигале язмышын сурәтләгән «Ак канатлы хатирәләр» (1990) романнарын яза. Әсәрләре рус, белорус һәм чуаш телләренә тәрҗемә ителә.

*Г.М.Габделхакова.*


**РӘКЫ́ЙПОВА** Лариса Рәкыйп кызы (26.6.1919, Литва-Белоруссия ССРның Минск өязе Ратомка ст.), геофизик, физика-матем. фән. д-ры (1959), проф. (1975). 1941 елда Ленинград ун-тын тәмамлаганнан соң, Ташкент геофизика обсерваториясендә эшли. 1942 дән Ярославль пед. ин-тында. 1943 тән Баш геофизика обсерваториясендә (Ленинград), атмосфераның гомуми циркуляциясе секторы башлыгы (1962 дән), атмосфера термодинамикасы һәм гелиофизика лаб-ясе мөдире (1973–83). Хезмәтләре атмосфераның җылылык режимы теориясенә, климатның антропоген һәм табигый үзгәрешләре өлкәсенә карый. Р. мезосфераның термодинамика һәм циркуляция режимнарына кояш активлыгының йогынтысы теориясен тәкъдим итә, космик тузанның стратосферадагы вертикаль хәрәкәтләргә һәм изотермиягә йогынтысын бәяли. Атмосфераның динамик һәм термодинамик режимына кояш активлыгы һәм антропоген факторлар тәэсиренең озонлы механизмын эшли (1972), соңрак бу механизм теориядә һәм тәҗрибәдә раслана. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О возможности влияния пыли на вертикальное движение воздуха // Изв. АН СССР. Сер. геогр. 1949. № 1; Тепловой режим атмосферы. Л., 1957; Эффекты солнечной активности в стратосфере. Л., 1980 (автордаш); Атмосферный озон и изменения глобального климата. Л., 1982 (автордаш).

**РӘМЗИ́** (Рамазанов) Шакир Махиян улы (1898, Уфа губ., Минзәлә өязе Аеш а. — 9.5.1938, Казан), журналист, тәрҗемәче. 1919 елда «Кызыл Шәрекъ» г-тасы, 1923–24 тә «Безнең байрак», «Татарстан» г-талары, «Кызыл Шәрекъ яшьләре» ж-лы, 1935–36 да «Кызыл Татарстан» г-тасы мөхәррире булып эшли. «Гарбдә яшьләр хәрәкәте» (1924), «Дин кемгә кирәк» (1926), «Сугыш белеме» (1927) һ.б. китаплар авторы. Сәяси әдәбият әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. 1937 нең 5 октябрендә, уң троцкийчы милли пантюркизм террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булуда гаепләнеп, кулга алына, атылуга хөкем ителә.

*Әд.:* Книга памяти жертв политических репрессий. К., 2004. Т. 12.

*Р.А.Айнетдинов.*



Б.И. Рәмиев.

**РӘМИ́ЕВ** Бәшир Искәндәр улы (15.5.1918, Оренбург губ., Орск ш. — 16.5.1994, Мәскәү), хисаплау техникасы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1962), РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1987). Шагыйрь Дәрдемәнднең оныгы. СССРда хисаплау техникасына нигез салучыларның берсе, «Урал» хисаплау машиналарының баш конструкторы. 1935 елда, Мәскәүдәге техник конкурста катнашучы буларак, Р. Бөтенсоюз уйлап табучылар җәмгыятенә әгъза итеп алына, урта мәктәпнең 10 сыйныфы өчен чыгарылыш имтиханнарын экстерн тәртиптә тапшырып (Уфа ш.), Мәскәү энергетика ин-тына кабул ителә (1938 дә, «халык дошманы» улы буларак, аннан чыгарыла). 1940 тан Үзәк элемтә фәнни-тикшеренү ин-тында техник (Мәскәү); Бөек Ватан сугышының башыннан СССР Элемтә министрлыгының шифрлау аппаратурасы эшләү буенча элемтә батальонында. 1944 тә хәрби хезмәттән азат ителә һәм, белгеч буларак, 108 нче Үзәк фәнни-тикшеренү ин-тына җибәрелә. 1948 дән СССР ФАнең Энергетика ин-тында (Мәскәү) инженер-конструктор. 1948 дә, СССР ФАнең мөхбир әгъзасы И.С.Брук б-н бергә, цифрлы электрон хисаплау техникасы өлкәсендә СССРда беренче уйлап табуга 10475 нче номерлы авторлык таныклыгын ала (шуңа бәйле рәвештә 1948 нең 4 декабре Россия информатикасының туган көне дип санала; 2008 дән рәсми төстә билгеләнеп үтелә). 1949–55 елларда СКБ-245 тә (Мәскәү), лаб. мөдире (1950–54), бүлек башлыгы (1954–55). Бер үк вакытта, 1951–53 тә, Мәскәү инженерлык-физика ин-тында укыта (цифрлы хисаплау техникасы буенча лекцияләр курсы укый). «Стрела» электрон-хисаплау машинасы (ЭВМ) — серияле беренче совет электрон-хисаплау машинасы (СССР Дәүләт бүләге, 1954) проектының авторы. 1955–68 дә Идарә итүче ЭВМнар фәнни-тикшеренү ин-тында (Пенза ш.) баш инженер һәм директор урынбасары, «Урал» тибындагы универсаль ЭВМнарның баш конструкторы.

1968–71 дә 3 нче буын ЭВМнар семьялыгын (3 нче буын ЭВМнарның Бердәм системасын) төзү буенча Электрон-хисаплау техникасы фәнни-тикшеренү үзәгенең баш конструкторы урынбасары. 1971–91 дә Фән һәм техника буенча СССР Дәүләт ком-тының Электрон-хисаплау техникасы һәм идарә итү системалары баш идарәсендә эшли. Р. җитәкчелегендә 18 типтагы махсус ЭВМ, ш.и. «Погода» (метеорология исәпләүләре өчен), «Гранит» (күзәтү нәтиҗәләренең ихтималый характеристикаларын исәпләү өчен), «Кристалл» (кристалларның рентген-структура анализы өчен), һәм аларга 100 дән артык периферия җайланмасы эшләнә һәм җитештерүгә кертелә. Техник фәннәр д-ры фәнни дәрәҗәсе күпләгән фәнни хезмәтләре буенча, диссертация якламый гына бирелә. 74 хезмәт авторы. Уйлап табуга 23 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Гомуми кулланылыштагы хисаплау комплекслары өчен унификацияләнгән операция системалары эшләгәне өчен СССР МС бүләге бирелә (1988). Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр; РСФСР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Анализ и синтез некоторых бесконтактных схем дискретного действия // Автоматика и телемеханика. 1959. Т20, № 1 (автордаш).

*Әд.:* М а л и н о в с к и й Б.Н. История вычислительной техники в лицах. Киев, 1995; Ч а с т и к о в А.П. Архитекторы компьютерного мира. СПб., 2002; Н и г м а т у л л и н Р.И. Воспоминания о добре и зле // Татарстан. 2008. № 10/11; Энциклопедия кибернетики. Киев, 1974. Т. 2.

**РӘМИ́ЕВ** Зөфәр Зәйни улы (25.6.1938, Кама Тамагы р-ны Уразлы а.), әдәбият галиме, текстолог, филол. фән. д-ры (2002), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1998). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2009). Казан ун-тын тәмамлый (1967). 1970 елдан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында: текстология төркеме җитәкчесе (1976–2006), бер үк вакытта кулъязмалар һәм текстология бүлеге мөдире (1996–97), директор урынбасары (2002–04), текстология бүлегенең баш фәнни хезмәткәре (2007 дән). М.Гафури (1980, 1 т.; 1983, 3 т.), Ф.Әмирхан (1989, 3 т.), Н.Думави (1985), С.Сүнчәләй (2005), Г.Исхакый (2005, 6 т.; 2012, 9 т., автордаш), М.Җәлил (1–5 т., 2006), Г.Тукай (2006, 2 т.), Г.Сөнгати (2007) әсәрләрен басмага текстологик әзерләү эшендә катнаша, «Татар шигърияте (XX гасыр башы)» (2004) антологиясен төзи. Г.Тукай, М.Гафури, Ф.Әмирхан, Г.Камал, С.Хәким, Ш.Маннур, Ә.Давыдов иҗатларына, текстология мәсьәләләренә, 20 нче йөз башы татар әдәбиятына, туган төбәкне өйрәнүгә багышланган хезмәтләр авторы. «Габдулла Тукай» энциклопедиясен төзү төркеме җитәкчесе (1996 елдан) һәм баш мөхәррире (2016). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2016).

Х е з м.: XX йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре. К., 2000; Тукай һәм замандаш әдипләр. К., 2004; Уразлы (Уразлино, Иске Каратай) авылы үткәненнән. К., 2004; Әдәбиятчы-текстолог язмалары. К., 2014; Текстология татарской литературы начала XX века. К., 2008.


*Әд.:* Әдәбиятчы, текстолог Зөфәр Рәмиев. К., 2008.

**РӘМИ́ЕВ** Исмәгыйль Габдулла улы (1.1.1895, Уфа губ. Эстәрлетамак ш. — 28.12.1969, Казан), библиограф, журналист. Туган шәһәре мәдрәсәсендә укый. 1911 елда Казанга килә, «Сәйяр» театр труппасында суфлёр булып эшли (1912–14). 1915–17 дә хәрби хезмәттә. 1917 дә Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтаена делегат итеп сайлана. Гражданнар сугышында катнаша; «Кызыл яу», «Кызыл йолдыз», «Кызыл дөнья» фронт г-талары редакцияләрендә эшли. 1922 дә Д.Юлтый б-н берлектә Уфада «Бабич» ж-лын чыгара башлый (тиздән совет органнары тарафыннан ябыла). 1925 тән Казанда. *Академүзәк* каршындагы әдәби мирасны бастыру комиссиясе сәркәтибе, «Чаян», «Яңалиф» ж-лларында, «Гажур» нәшриятында, «Яңалиф» җәмгыятендә; 1930 дан *Татгосиздат*та эшли. Татар теленең орфографик һәм терминологик сүзлекләрен төзи. Татар теленә С.М.Степняк-Кравчинскийның «Яңа көчләр» («Новообращённый», 1920) драмасын, А.П.Чеховның «Футлярдагы кеше» («Человек в футляре», 1936) хикәясен тәрҗемә итә. Энциклопедия характерындагы «*Вакытлы татар матбугаты*» басмасы авторы. 1937 дән Урта Азиядә яши. 1942–44 тә Хезмәт армиясендә. 1945 тән Кайбычта яши, район г-тасы редакциясендә, мәдәният сараенда эшли (1956 га кадәр). 1961 дән янә Казанда. «Истәлекләр. Татарча басма сүз» җыентыгы (1956), татар мәдәнияте һәм революциягә кадәрге татар әдәбияты эшлеклеләренә багышланган «Әдәби сүзлек» биобиблиографик белешмәлек авторы (Р.Н.Даутов тарафыннан 2001 дә тулыландырылган вариантта кабат чыгарыла).

*Р.Н.Даутов.*

**РӘМИ́ЕВ** Октябрь Әмир улы (25.10.1932, БАССРның Эстәрлебаш р-ны Эстәрлебаш а. — 10.10.2003, Мәскәү), геолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984), геол.-минерал. фән. канд. (1969), РФнең атказ. геологы (1994). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1955), «Башвостокнефтегазразведка» трестында эшли. 1968–79 елларда (бүленеп) «Главтюменьгеология» идарәсендә (1970–73 тә Алжирда командировкада). 1973–75 тә Төмән индустрия ин-тында укыта. 1979 да Мәскәүдә РСФСР Госпланының геол. бүлегендә баш белгеч, 1992 дән Россия геол. ком-тының геол. һәм лицензия бирү идарәсе башлыгы, 1994–2000 дә «Деминекс» һәм «Винтерсхале» немец компанияләре эксперты. Дәүләт бүләге Ямбург газ конденсатлы чыганакны ачкан һәм сәнәгый үзләштерүне тизләткән өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**РӘМИ́ЕВ** Сәгыйт Лотфулла улы (12.2.1880, Оренбург губ. Акман (Ибрай) а. — 16.3.1926, Уфа ш.), шагыйрь, драматург, прозаик, журналист, публицист, тәрҗемәче, театр белгече. Р. нең шәҗәрәсе шагыйрь-философ *Дәрдемәндкә* (Закир Рәмиев) барып тоташа. Р. сал агызучы гаиләсендә дөньяга килә. 11 яшенә кадәр Илек шәһәрендә башлангыч мәктәптә, 1890–1902 елларда «Хөсәения» мәдрәсәсендә (Оренбург ш.) укый; татар мәдрәсәләрендә уку-укыту системасын яңарту өчен



С. Рәмиев.

барган шәкертләр хәрәкәтендә катнаша. Соңрак бу вакыйгалар «Низамлы мәдрәсә» (1907) пьесасында чагылыш таба. Иҗат юлын Р. 1905–07 елгы рев-ция елларында *гыйсьянчылык* романтизмы, халыкчанлык, революцион-демократик һәм социалистик идеяләр б-н үрелгән мәгърифәтчелек романтизмы шагыйре буларак башлап җибәрә. Беренче шигырьләрендә татар халкын мәгърифәткә өнди, рус мәдәниятен үзләштерергә теләгән мәдрәсә шәкертләренә каршы чыккан феодаль яшәеш тарафдарларын кискен тәнкыйтьли («Хәзрәтләр эше. Муллаларга»); «наданлык сазлыгына баткан» татар хатын-кызларын уяныргa, белем алырга, үз хокуклары өчен көрәшергә чакыра («Хатыннар галәме»); шәкертләр арасындагы фәкыйрьлекне каргый, аны иҗтимагый гаделсезлек, кеше абруен кимсетү дип бәяли.

Р.нең әдәби иҗатын Казан, Әстерхан, Уфа чорларына бүлеп карарга мөмкин. Төрле идея-эстетик юнәлешләрне (соц. һәм модернистик) берләштергән, Казанда яшәп иҗат иткән 1906–10 еллар иң бай чор дип исәпләнә. Бу елларда ул поэзия, проза, драматургия өлкәсендә уңышлы эшли. Г.Исхакыйның «Таң йолдызы», «Тавыш», «Таң мәҗмугасы» кебек әсәр басмаларында талантлы журналист буларак царизмның хәрби-полиция режимына каршы юнәлтелгән күпсанлы публицистик мәкаләләр, шигырьләр («Бел телен, эзлә юлын», «Әгәр баксаң гәзиттәге хәбәрләргә» һ.б.), революцион җырлар («Татарча Марсельеза», «Матәм маршы», «Кыю атлагыз, иптәшләр!», «Таң ата, эшлик, туганнар!») бастыра. Шуның өчен Р. дәүләт җинаятьчесе дип игълан ителә, төрмәдә утырып чыга. Татар театрының нигез ташларын салуда да актив катнаша, аның рәсми ачылышында (1906 ның 22 дек.) ялкынлы чыгыш ясый. Әлеге мөһим тарихи-мәдәни вакыйгага Р. «Театр» (1907) публицистик шигырен багышлый. 1907–10 да «әл-Ислах», «Волжско-Камская речь» г-таларында (рус теленә тәрҗемә ителеп) дөнья күргән шигырьләре аны әйдәп баручы татар шагыйре дәрәҗәсенә күтәрә. «әл-Ислах» г-тасы ябылганнан соң (1909), Р. «Казан мөхбире» г-тасының «Без» исемле сатирик-юмористик эчтәлекле кушымтасын җитәкли. «Бәянелхак» г-тасында М.Метерлинкның «Күк кош» («Синяя птица», 1909) исемле әкият-драмасын тәрҗемә итеп бастыра, яңа чыккан китапларга багышланган рубрика алып бара, Шәрекъ, Яңа һәм Сәүдәгәрләр клубларының татар җәмәгатьчелеге арасында мәдәни-агарту эшчәнлеге турында күзәтүләр бастыра; «Себектүгин» тәхәллүсе б-н спектакльләр куюда, әдәби-муз. кичәләр үткәрүдә катнаша. 1905–07 елгы рус рев-циясенең җиңелүе, иҗтимагый-сәяси, милли идеалларның тормышка ашмавы Р.нең алгарышка бару турындагы өметләрен өзә. Ул инкыйлаб, сыйнфый көрәш

темаларына язмый башлый, шәхеснең рухи азатлыкка омтылышын яклаган индивидуализм позициясенә күчә. Шигъриятендә яшәп килүче иҗтимагый тәртипләр б-н каршылыкка килгән гыйсъянчы шагыйрь образы калкып чыга: «Әрни-әрни ләгънәт әйтәм / Тискәре бу дөньяга...» («Алданган»).

Дөньяга карашларында кискен үзгәрешләр тудырган «Таң вакыты» (1907) шигыре б-н Р. иҗатының модернистик шигъриятькә бәйле сәхифәләре ачылып китә. Шагыйрь «таң вакыты» һәм «кояш» образ-символлары ярдәмендә татар халкы тормышында башланып киткән рухи уяну һәм яңарыш чоры башлануны куанып сәламли. Кояш калка, әмма татарлар, уянырга куркып, йоклауларын дәвам итәләр, гасырдан гасырга күчә килгән, фаҗига б-н янаган иске фикерләр әсирлегендә калалар. Тирән тамырлары, бихисап ботаклары, куе яфраклары б-н җир өстен каплаган зур агач образ-символы ярдәмендә автор татарның хатасын — «язмыштан узмыш юк» фәлсәфәсенә буйсынып яшәвен тәнкыйтьли, Аллаһ мәрхәмәтен көтеп ятмыйча, үз көченә ышанып иҗтиһад итү, гыйлем өстәп, рухи яңару гына мөселманнарны наданлыктан, инкыйраздан коткарып калачак, тәрәккыятькә илтәчәк, дигән фикерне үткәрә: «Бул кеше, үзең тырыш, өмид итмә, / Хата ул өмид Алладан! / Бетмә надан, туг яңадан / Мәгърифәтле анадан».

Татар җәмәгатьчелеген аякка бастырган «Мин» (1908) шигыре тулысы б-н атаклы немец философы Ницшеның көчле шәхес культы б-н сугарылган. Аның «зур ихтыяри көч»кә ия булган романтик герое күк аллалары һәм җир хакимнәренә гыйсъян игълан итә: «Мин!» димен мин, «мин» дидисәм, / Миңа бер зур көч керә, / Аллалар, шаһлар, кануннар / Булалар бер чүп кенә».

Гаделсез кешелек җәмгыятенә һәм бөтен Галәмгә каршы юнәлтелгән гыйсъянчылык «Дөньяга» (1908) шигырендә дә чагылыш таба: «Әмма соң бер эт итеп бу / Дөньяны атар идем, / Җир-суын да яндырып һәм / Күкләрен ватар идем!..» Ялганга, дошманлыкка корылган дөньяга шагыйрь «Алданган» (1908) шигырендә ләгънәт укый.

Шәрекъ мөселман әдәбияты һәм русларның «Көмеш гасыр» шагыйрьләре традицияләре рухында яктыртылган үлем темасы Р.нең байтак шигырьләрендә кара экзистенциаль җеп сыман үрелеп бара («Мин үләм», 1908; «Күрәм гали...», 1909; «Дөньяга», 1919 һ.б.).

Р. — күп кенә лирик шигырьләр авторы да. Аның «Ул» (1908), «Син» (1908), «Кайвакытта уйлыймын мин» (1908), «Минутлар» (1908), «Бер кеше» (1909), «Җәмилә» (1909) шигырьләрендә, пантеистик суфичылык поэзиясендәге кебек, сөйгән ярны илаһи образ-символ дәрәҗәсенә күтәргән романтик мотивлар өстенлек итә. Русларның «Көмеш гасыр» философлары һәм шагыйрьләре кебек, ул да матурлык һәм мәхәббәт гармониясенә сусаган, бәргәләнү-өзгәләнүләрдән арыган, талчыккан иҗади шәхесне коткару миссиясен гүзәл хатын-кыз образына тапшыра һәм лирик геройның бу авыр халәтен чын философларча антиномиягә корылган ут һәм су образ-символлары ярдәмендә гәүдәләндерә. «Син» шигырендә бу аеруча ачык күзәтелә: «Мине утка аткан ул — син, / Мине суга салган да — син, / Утта янсам, суга батсам, / Тартып алган Аллам да — син!»

Этик идеал һәм бәхет символы рәвешендә сурәтләнгән илаһи мәхәббәт темасы «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!» (1907) романтик драмасының да үзәген тәшкил итә.

Дөньяга карашларда, сәнгатьчә фикерләүдә модернизмга йөз тоткан елларда Р. Ж.-Ж.Руссо фәлсәфәсе тарафдары була: ул авыл табигатенең сафлыгын, авыл кешеләренең әхлакый пакьлеген романтикларча идеаллаштыра («Авыл», 1908); А.С.Пушкинның «Пророк» («Пәйгамбәр», 1909); М.Ю.Лермонтовның «Перчатка» (1910) шигырьләрен татар теленә тәрҗемә итә. 1909 да «Нәҗметдин агай бәйрәме», «Галәветдин хаҗи корбаны — Җаек Хәдичә» исемле хикәяләрен, «Ул исерек түгел иде» повестен яза.

1910–14 тә Р. Әстерханда яши, «Идел» г-тасында сәркәтип, соңрак рәсми булмаган мөхәррир вазифасын башкара. Шәһәр һәм төбәк төрки-татар халкы арасында иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни-агарту эшләре алып бара; бирегә сөргенгә җибәрелгән әзәрбайҗан язучысы һәм табибе Н.Нариманов б-н дуслаша (Нариманов — режиссёр, үзе актёр булып бергә спектакльләр куялар). «Идел»дә эшләгәндә нугайлар турында этнографик очерклар бастыра, әдәбият, театр, музыка, медицина мәсьәләләренә, мәгърифәтче-драматург М.Ф.Ахундов, Н.Нариманов, татар большевигы Х.Ямашев эшчәнлегенә багышланган мәкаләләр яза; «Яшь шагыйрьләр өчен киңәшләр» рубрикасын алып бара; төрки-татарларның язуларын гарәп графикасыннан латин хәрефләренә күчерү кирәклеге мәсьәләсен күтәрә. Иҗатының Әстерхан чорында рус кызы Татьянаның татар егете Хәмиткә фаҗигале мәхәббәтен сурәтләгән «Кабакта мәхәббәт» шигъри романтик драмасын иҗат итә (1910, басылмаган); Л.Толстой истәлегенә багышлап мәкаләләр циклы һәм «Ул үлде» (1910) шигырен яза, аның «Живой труп» («Тере мәет», 1910) драмасын татар теленә тәрҗемә итә. Р. чакыруы буенча бер ай дәвамында Әстерханда шагыйрь Тукай кунак булып китә. 1914 ел башында хакимияткә каршы юнәлтелгән мәкаләләре өчен «Идел» г-тасы ябыла, «сәяси яктан ышанычсыз» дип табылган Р.кә тиз арада Әстерханнан китәргә әмер бирелә. Шагыйрь Уфага күчеп китә, «Уфимский сельскохозяйственный листок» ж-лы редакциясендә тәрҗемәче булып эшли, татар телендә «Уфаның авыл көнкүреше журналы»н чыгара, анда М.Ю.Лермонтов, Н.А.Некрасов, А.П.Чехов, Д.Бедный әсәрләренең тәрҗемәләрен, ш.у. М.В.Ломоносов, Л.Н.Толстой, И.И.Мечников юбилейлары турында мәкаләләр бастыра. 1915 тә Уфада «Сәгыйт Рәмиевнең яңа шигырьләре һәм әүвәлгеләре» җыентыгы дөнья күрә.

1916 ның гыйнварында патша охранкасы Р.не Уфа жандармериясенең агентура эшчәнлегенә тартырга омтылыш ясый. Бу факт җәмәгатьчелеккә мәгълүм булгач, шагыйрь турында гайбәтләр тарала, ул шымчылыкта гаепләнә. «Дога» (1916), «Тәсәллә»(1918), «Алар»(1918), «Талдым» (1918) кебек шигырьләреннән аның бу хәлләрне бик тә авыр кичерүе аңлашыла: «Илаһым, ал мине! Талдым, / Юлыңда бер үзем калдым, / Куям кылчым кире кынга.../ Газаплый тик синә антым...».

1918–19 да Ваһапов посёлогында ревком секретаре, Оренбург губернасы Верхнеуральск өязе Магнитная станицасында халык мәгарифе бүлеге мөдире вазифаларын башкара. 1920–22 дә РКП(б)ның Верхнеуральск шәһәр ком-ты мөселман секциясе б-н җитәкчелек итә, Чиләбедә милләтара эшләр инспекторы булып эшли. Биредә үк «Кызыл Урал» г-тасында «Саботаж» (1921), «Иблис тә дердерәде» (1920) хикәяләрен бастыра; пед. техникумында татар теле укыта. 1922 ел ахырында Уфага кайта, Башкортстан АССРның Җир эшләре халык комиссариатында нәшрият бүлеге б-н җитәкчелек итә, Башкортстанны өйрәнү җәмгыяте эшендә катнаша, башкорт мәктәпләре өчен дәреслекләр әзерләү буенча Академүзәк секциясе әгъзасы була, башкорт теле орфографиясенең беренче проектын төзи һ.б. 1923 тә үпкә туберкулёзы б-н авырый башлый. Бу чорда Р. азрак яза, күбрәк тәрҗемә б-н шөгыльләнә. Татар теленә партия гимны «Интернационал»ны (1923), Р.Джованьолиның «Спартак» романын (1923), Софоклның «Эдип патша» («Царь Эдип», басылмаган) трагедиясен тәрҗемә итә. Кайбер замандашлары Р.не рев-циягә хезмәт итүдән туктауда, «каләме тутыгуда» гаеплиләр. Аларга җавап рәвешендә язылган «Сүзем һәм үзем» (1923) шигырендә Р. уй-хыялларының тормышка ашачагына өмет белдерә, чөнки әле аның каләме тутыкмаган, әйткән сүзе көчле һәм мәгънәле, ул әле һаман да «сәгадәтне идеал күрә», аның өчен «һаман да янарга әзер»: «Сәгадәттән бер дә өмет кискәнем юк; / Хәят белән арам төенен чишкәнем юк».

Р. һәр каләм иясенең иҗат ирегенә хокукын яклый, озак гасырлар дәвамында көйлелеккә таянган, тигез иҗекләр санына корылган силлабик шигырь төзелешен интонацион ритмиканың яңа формалары һәм дөньяви яңгыраш б-н баета. Яңа ачышлар б-н тулы Р. шигърияте бүген дә татар халкының рухи яңарышка омтылышына һәм шәхес азатлыгына гимн булып яңгырый. Р. озакка сузылган каты авырудан вафат була.


Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1962; Таң вакыты. К., 1980; Әсәрләр. К., 2005 (автордаш).

*Әд.:* Садретдинов Ш. Сәгыйт Рәмиев иҗаты. К., 1973; Зарипова-Четин Ч. «Уйласам уй, сызлый күңлем, сызлый җан...» К., 2005; Ганиева Р. Сәгыйт Рәмиев — гыйсъянчылык романтизмы шагыйре // Татар әдәбияты: традицияләр, багланышлар. К., 2002; Халит Г. Многоликая лирика. К., 1990; Зарипова-Четин Ч. Проблема демонизма в творчестве С.Рамиева в контексте восточно-европейской эстетики. К., 2003.

*Р.К.Ганиева.*

**РӘМИ́ЕВЛӘР**, Оренбург төбәге сәүдәгәрләре һәм алтын приисклары хуҗалары, җәмәгать эшлеклеләре. **Габделкәрим Исмәгыйль улы** (1774, Самара губ., Бөгелмә өязе Тай-


Мөхәммәдзакир Рәмиев (Дәрдемәнд).


Мөхәммәдшакир Рәмиев.

суган а. — 1851, Оренбург губ., Эстәрлетамак өязе) — Р. нәселенең башлыгы. Эстәрлетамак өязендә сәүдә итә. **Мөхәммәдсадыйк Габделкәрим улы** (1828, Ергән а. — 22.4.1892, Оренбург губ., Орск өязе Юлык а.) атаклы *Дашкиннар* нәселеннән Хәнифә Әлмөхәммәд кызына өйләнә. 1862 елда Юлык авылына килеп урнаша, сабын з-ды сатып ала, күн әйберләр җитештерү з-ды ача. Орск өязенең Ишбирде авылы янындагы беренче алтын приискын 1869 да статский советник Шиповтан сатып ала. **Мөхәммәдсадыйкның уллары Мөхәммәдшакир** (5.3.1857, Ергән а. — 15.3.1912, Оренбург ш.) һәм **Мөхәммәдзакир** (23.11.1859, Ергән а. — 9.10.1921, Оренбург губ. Орск ш.) — 1 нче гильдия сәүдәгәрләр. Орск өязенең Орск шәһәре Муллакай авылы мәдрәсәсендә укыйлар. Аталарының эшләрен дәвам итәләр, 20 йөз башына Көньяк Уралда 30 дан артык алтын приисклары була, шуларның унбише Орск өязенең 1 нче һәм 2 нче Бөрйән волостьларында урнашкан. 19 йөз ахырында Р. приискларында 850 кеше эшли. Иң зур алтын приисклары Оренбург губернасының Верхнеуральск өязе Балкан авылы янында урнашкан (алтын ятмалары 1895 тә ачыла). Балкан авылында Р.нең җәй айларында ял итү өчен кунак йорты була (М.Гафуриның «Шагыйрьнең алтын приискасында» автобиогр. повестенда телгә алына, 1929). Р. үз акчаларына Юлык авылында мәчет салдыралар, мәчет каршындагы мәктәпне карап торалар. 19 йөз ахырында Р. Оренбургка күченәләр. 1902 дә Мөхәммәдшакир, Көнбатыш Европага барып, алтын табуның яңа ысулларын өйрәнеп кайта. Заманча җиһазлар сатып алып, үзенең тәҗрибәсенә һәм инженерлык сәләтенә таянып, аларны шәхси приискларында эш шартларына яраштыра. Р. приискларындагы техник яңалыклар турындагы мәкаләләре Россия һәм чит ил журналларында басыла; аның алтын юдыру агрегатын камилләштерү турындагы тәкъдиме аерым әһәмияткә ия. Мөхәммәдзакир Оренбург казна палатасы каршындагы алтын приисклары хуҗалары съездының ышанычлы вәкиле була. Бертуган Р. 1880 елларда И.*Гаспринский* һәм аның «*Тәрҗеман*» г-тасы тәэсирендә нәшрият эше б-н кызыксына башлыйлар. «Тәрҗеман» г-тасының иганәчеләре булалар, үз газеталарын булдырырга да омтылалар. 1898 дә Мөхәммәдшакир Европа, С.-Петербург, Мәскәү басмаханәләрендә, ш.и. мәшһүр И.М.Бораганский (С.-Петербург) басмаханәсендә нәшрият эшенең оештырылуы б-н таныша. 1902–03 тә Р., татар телендә газета чыгарырга рөхсәт сорап, кат-кат мөрәҗәгать итәләр, әмма рөхсәтне 1906 да гына алалар. Үз акчаларына Оренбургта «*Вакыт*» г-тасын нәшер итәләр (1918 гә кадәр 20 йөз башында иң абруйлы басмаларның берсе). Мөхәррир итеп язучы Ф.*Кәримине* чакыралар. Көнбатыш Европа илләренә барганда ул Мөхәммәдшакирның тәрҗемәчесе була. Ф.Кәриминең этисе Г.Кәримигә бертуган Р. Оренбургта басмаханә сатып алырга ярдәм итәләр, баштарак анда «Вакыт» г-тасы нәшер ителә (к. «*Кәримов, Хөсәенов вә шөркәсе басмаханәсе*»). 1908 дә Р. акчасына «Вакыт» г-тасына кушымта булып «*Шура*» ж-лы нәшер ителә башлый (1918 гә кадәр), мөхәррире итеп Р.*Фәхретдин* билгеләнә. 1909 да Р. шәхси «*Вакыт*» ташбасмаханәсен ачалар. Ул иң яхшы җиһазланган татар матбагаларының берсе була.

Р. татар телендә китаплар чыгаралар, хәйрия эше б-н шөгыльләнәләр, сәләтле студентларга ярдәм итәләр. Шагыйрь *Дәрдемәнд* исеме б-н билгеле Мөхәммәдзакир иҗтимагый-сәяси, мәдәни-агарту эшчәнлеге б-н шөгыльләнә. Р. гаиләсе Оренбургның татар интеллигенциясе б-н тыгыз мөнәсәбәттә була. 1918 дә Мөхәммәдзакир үз пр-тиеләрен совет хакимиятенә тапшыра. Төркия дипломаты һәм тюрколог Г.*Айда* б-н Мөхәммәдзакирның оныгы конструктор Б.И.*Рәмиев* — бертуган Р. нәселенең дәвамчылары.

*Әд.:* Ф ә х р е т д и н Р. Мөхәммәдшакир әфәнде Рәмиев // Шура. 1913. № 6; Бертуган Рәмиевләр: Фәнни-биографик җыентык. К., 2002; Дәрдмәнд. К., 2003. *Р.А.Айнетдинов.*

**РӘСҮ́ЛЕВ** Габдрахман Зәйнулла улы (10.10.1881, Уфа губ., Златоуст өязе Акхуҗа а. — 5.7.1950, Уфа), дин эшлеклесе, З.*Рәсүлев* улы. 1899 елда «Рәсүлия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң хаҗ кыла. 1902 дә «әл-Әзһар» ун-тын тәмамлый (Каһирә ш., Мисыр). 1902–17 елларда «Рәсүлия» мәдрәсәсендә укыта һәм аның б-н җитәкчелек итә (1903 тән), бер үк вакытта (1905 тән) Оренбург губернасындагы Троицк каласы мәчетенең имамы була. 1923 тән Урал өлкәсе мөхтәсибе. 1936–50 елларда СССРның Европа өлешендәге һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие; Диния нәзарәтен саклау һәм мөселман руханиларын 1930 еллардагы сәяси репрессияләрдән коткарып калу өчен күп эшли. 1942 дә «Труд» г-тасында Р.ның Сов. Союзы мөселманнарына мөрәҗәгате басылып чыга. Анда ул сов. хөкүмәтенең мөселман җәмәгатьчелеге ихтыяҗларын кысу сәясәтеннән баш тартуын, мәчетләр төзергә, дини йолаларны ирекле башкарырга рөхсәт бирүен хәбәр итә һәм мөселманнарны фашизмга каршы көрәшкә чакыра. Мөфтинең мөрәҗәгате диндарлар арасында зур яклау таба, алар тарафыннан җыелган акча танк колоннасы төзергә җибәрелә. Р. бу хакта И.В.Сталинга телеграмма юллый. Бу дәүләтнең дини сәясәтен либеральләштерүдә зур роль уйный. Сугыштан соңгы елларда Р. диндарларның һәм мөселман руханиларының мәнфәгатьләрен яклавын дәвам иттерә: дини җәмгыятьләрне теркәүгә, мәчетләрне диндарларга кайтарып бирүгә булышлык итә. Теркәлмәгән мөселман җәмгыятьләрендәге муллаларга дини йолалар башкару өчен шәһадәтнамәләр тапшыра. «Ислам» (М., 1945; 2 басма, М., 1998) китабы авторы.

*Әд.:* Р а х м а н к у л о в а С.Г. Муфтий Габдрахман Расулев — старший сын Ишана хазрата Расулева. Челябинск, 2000; Ислам на территории бывшей Российской империи: Энцикл. словарь. 2003. Т. 4.

**РӘСҮ́ЛЕВ** Зәйнулла (28.3.1833, Оренбург губ., Троицк өязе Шәриф а. — 2.2.1917, Троицк ш.), дин эшлеклесе, Троицкида мәдрәсә тәмамлаганнан соң (1859), мөдәррис һәм имам-хатип булып эшли (Оренбург губернасындагы Югары Урал өязе Акхуҗа авылы). 1869 елда шәех Габделхәким тарафыннан *Нәкышбәндийә* суфилар борадәрлегенә кабул ителә. 1869–70 тә Р. Мәккә, Истанбул шәһәрләренә бара. Сәфәрдән кайткач, җирле мөселманнар эшчәнлегенә суфичылык йолаларын кертергә тырышып карый, әмма рәсми ислам вәкилләренең җитди каршылыгына очрый; аларның шикаяте буенча 1873 тә Костромага сөргенгә җибәрелә. Ирекә чыккач, 1881 дә икенче тапкыр хаҗ кыла. 1884 тән Троицк мәчетендә имам-хатип булгач, ул нигезләгән «*Рәсүлия*» мәдрәсәсе җәдиди ысул б-н эшли башлый. Р. җәдитчеләр арасында да, кадимчеләр арасында да зур абруй казана; татар, башкорт, казакъ шәкертләре арасында бик күп мөритләр тәрбияли. Табиблек талантына ия була.

*Әд.:* Ф ә х р е т д и н Р. Зәйнулла хәзрәтнең тәрҗемәи хәле. Оренбург, 1917; Р а с и х А. Ишан оныгы // Казан утлары. 1990. № 1; Б а р т о л ь д В. Шейх Зайнулла Расулев // Мусульманский мир. П., 1917. Вып. 1; Валидов Дж. Очерки по истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.). М.–П., 1923.

**РӘСҮ́ЛЕВА** Фәридә Атилла кызы (29.7.1948, Казан), шагыйрә. Рус телендә яза. Ташкент ун-тын (1974), А.М.Горький исем. Әдәбият ин-тын (Мәскәү, 1984) тәмамлый. «Пролог» (1984), «Салкын иртә» («Холодное утро», 1989), «Вакыт уза» («Кончается время», 2006), «Чыңгызханның алтын быргысы» («Золотая труба Чингиз-хана», 2007) шигъри җыентыклары авторы. Башлангыч чор лирикасына эчкерсезлек, самимилек хас. Тора-бара Р. поэзиясе фәлсәфи юнәлеш ала.

**«РӘСҮЛИЯ́»**, Оренбург губернасының Троицк шәһәре 5 нче җамигъ мәчет каршындагы мәдрәсә. 1884 елда З.*Рәсүлев* ача. Аның авторитеты һәм пед. осталыгы ярдәмендә мәдрәсә 1880 еллар ахырына зур мөселман уку йортына әверелә. 1890 елларда анда 200 дән артык укучы (татар, башкорт, казакъ балалары), 1900 ләрдә 400 кеше укый. Беренче елларда дәресләр гадәти системада алып барыла, әмма З.Рәсүлевнең новаторлык карашлары б-н Коръән тәфсирләрен генә түгел, ә Коръән һәм хәдисләрнең үз текстларын, ш.у. Г.Курсави, Ш.Мәрҗани хезмәтләрен өйрәнүгә зур игътибар бирелә. 1893 тән укырга-язарга өйрәтү аваз алымы буенча алып барыла, 1900 гә сыйныф-дәрес системасы, рус теле кертелә. З.Рәсүлев радикал җәдитчелеккә каршы була һәм «Рәсүлия» мәдрәсәсендә укыту дини формада кала. Башта мәдрәсә казакъ бае Ал-

тынсарин акчасына төзелгән ике катлы агач бинада урнаша. 20 йөз башында З.Рәсүлев, сәүдәгәр Габбасовлар һәм Яушевлар акчасына 2 ике катлы таш бина сатып алына һәм үзгәртеп корыла.

1905 тә З.Рәсүлевнең улы Габдрахман мөдәррис итеп куела, аның вакытында укыту курсларына дөньяви фәннәр: татар һәм рус телләре, төрки һәм гомуми тарих, математика, физика, химия, зоология, педагогика кертелә. «Рәсүлия» мәдрәсәсендә М.*Гафури*, Х.Ф.*Искәндәров*, Ш.Ш.*Хыялетдинов* һ.б. укый. 1919 да мәдрәсә ябыла.

*Әд.:* Фархшатов М.Н. Народное образование в Башкирии в пореформенный период: 60–90-е годы XIX в. М., 1994.

**РӘҮ́ФОВ** Рәфыйк Рәүф улы (5.1.1941, Кукмара р-ны Татар Толлысы а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТССР, РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1990, 1998). Лаеш а.х. техникумын тәмамлый (1973). 1957–2006 елларда (бүлеп) «Новая жизнь» ҖЧҖтә (1992 гә кадәр колхоз) эшли: тракторчы, колхоз рәисе (1978 дән), арендаторлар берлеге рәисе (1992 дән), аның директоры (2000 нән); 1976–78 дә Кукмара р-нының «Заветы Ильича» к-зы рәисе. Р. җитәкчелегендә җитештерү, мәдәни-көнкүреш объектлары, торак йортлар, Чарлы урта мәктәбе төзелә, авылларга газ кертелә. 2005 тә 1 *га* дан 41,2 *ц* бөртекле культуралар, 302 *ц* бәрәңге алына, еллык савым 1 сыердан 5890 *кг* тәшкил итә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Сибат Р. «Без дә җирдән күтәрелдек...». Яр Чаллы, 2003; шул ук. Көзге Сабантуй. К., 2005; Сибат Р., Хаҗиев М. Бәхет бишегем Толлы (документаль повестьлар). Яр Чаллы, 2000; Сибат Р. Крутой подъём // Идель. 2001. № 1.

**РӘФИКЫ́Й** Гали Лотферахман улы (29.6.1890, Уфа губ., Бәләбәй өязе Баязит а. — 11.3.1944, Бәләбәй ш.), журналист, язучы, тәрҗемәче. «Галия» мәдрәсәсендә (Уфа ш.) укый. Казан татар укытучылар мәктәбен (1915), Башкортстан пед. ин-тын (1930 еллар) тәмамлый. Кыргызстанда укытучы булып эшли. 1917 дән соң Башкортстанда пед. эштә (Бәләбәй татар-башкорт пед. техникумында һ.б.). «Шура», «Аң», «Ак юл», «Белем», «Культура революциясе» ж-лларында, «Вакыт», «Башкортстан», «Яңа авыл» г-таларында мәкаләләре басыла. «Алатау буйларында» (1913), «Вакытлы никах» (1913), «Артык кеше» (1914) һ.б. очерк һәм хикәяләр җыентыклары авторы. И.С.Тургенев, А.И.Куприн әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Урта мәктәпләр өчен рус теле дәреслеге авторы.

**РӘ́ФЫЙКОВ** Басыйр Шаһинур улы (10.2.1921, Мамадыш ш.), шагыйрь. Магнитогорск пед. ин-тын тәмамлый (1947). 1948–59 елларда Чиләбе өлкәсе Троицк татар-башкорт пед. уч-щесендә тарих укыта, соңрак директор урынбасары була. 1960–76 да шул ук шәһәрнең урта мәктәпләрендә уку-укыту бүлеге мөдире, соңрак директор. «Җырым сиңа минем» (1968), «Кадерле минутлар» (1971), «Туган тупсалар» (1981), «Кара каен — Чёрная берёза» (рус һәм татар телләрендә,Чиләбе, 1986), «Вакыт җиле» (1991), «Степь» (русчага тәрҗемә, Троицк, 1993), «Времени бег» (русчага тәрҗемә, Троицк, 1995) җыентыклары авторы. Иҗатында мәхәббәт лирикасы, фольклор мотивлары өстенлек итә. Халык арасыннан фольклор ядкәрләрен җыю б-н шөгыльләнә. Аның тарафыннан язып алынган утызлап мәзәк «Мең дә бер мәзәк» (төзүчесе Г.Бәширов, 1963) җыентыгына кертелгән. Р.ның кайбер шигырьләре комп. Р.Бакиров тарафыннан көйгә салына. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әсәр.:* Избранная лирика. Троицк–Челябинск, 2001.

**РӘФЫ́ЙКОВ** Габдрахман Вәли улы (1.3.1873, Казан — 3.5.1954, шунда ук), педагог, мәгърифәтче. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый, 1894 елда Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлый. Тәтеш өязе Чирмешән авылының рус-татар уч-щесендә укытучы, 1896 дан Казанның Адмиралтейство бистәсендә 2 нче шәһәр рус-татар уч-щесендә. 1900–17 дә Р. Казан губернасы халкына чәчәк салуны пропагандалый һәм оештыра. 1908 дә Казанның нәселдән килгән мактаулы гражданы итеп тәгаенләнә. Окт. рев-циясеннән соң татар мәктәпләрен дәүләт челтәренә күчерүдә, өлкәннәр арасында наданлыкны бетерүдә, эшче кооперативлар оештыруда зур роль уйный. 1921–35 тә Казанда рус-татар уч-щесеннән үзгәртелгән 13 нче мәктәп (соңрак 17 нче мәктәп) директоры, бер үк вакытта, 1921–24 тә, ТАССР Мәгариф халык комиссариаты президиумы әгъзасы һәм инспекторы. Соңрак Казан шәһәре мәктәпләрендә укытучы булып эшли. Революциягә кадәр рус-татар уч-щеләре өчен уку ярдәмлекләре чыгара, башлангыч мәктәпләр өчен татар телендә беренче совет дәреслекләре авторы (Ф.Әмирхан б-н) (1918). 11–13 чакырылыш Казан шәһәр советы депутаты (1924–28). Хезмәт Герое (1924). Казанда бер яңа урам Р. исеме б-н атала.

*Хезм.:* Кыйраәт китабы: Хәсән бабайның бал корты турында файдалы сүзләре. К., 1898; Счёт кагыйдәләре. К., 1910.

*Әд.:* Егерме биш еллык хезмәт // Әмирхан Ф. Сайланма әсәрләр. К., 1958. Т. 2; Ханбиков Я.И. Татарские педагоги-демократы конца XIX — начала XX вв. // Уч. зап. Казан. гос. пед. ин-та. 1976. Вып. 171; Жизнь, отданная людям. К., 2012.




Г.В.Рәфыйков.



И.В.Рәфыйков.


**РӘФЫ́ЙКОВ** Гали Мөхәммәт улы (18.7.1936, Ленинград), терапевт, физиолог, мед. фән. д-ры (1992). Ленинградның 1 нче мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), Новгород өлкәсендә участок хастаханәсе мөдире булып эшли. 1962 елдан Мәскәү ун-тының кеше һәм хайваннар физиологиясе кафедрасында. 1965 тән Мед.-биол. проблемалары фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү). 1970 тән Ленинградның 1 нче мед. ин-тында. 1973 тән проф. А.Л.Поленов исем. Россия нейрохирургия ин-тында әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (С.-Петербург). Хезмәтләре нейрохирургиядә гипербарик оксигенлаштыру куллануга карый. Уйлап табуга 8 патенты бар. 1991–93 елларда С.-Петербургта Татар мәдәни үзәге идарәсе әгъзасы.

**РӘФЫ́ЙКОВ** Искәндәр Вәлиулла улы (5.10.1929, Казан), нәкышьче, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1980), ТАССРның, РФнең халык рәссамы (1990, 2007), проф. (1995), Россия Сәнгать академиясенең шәрәфле әгъзасы (2014). Казан сәнгать уч-щесен (1949), Латвия ССР САнең (Рига) Я.Тильберг җитәкләгән станлы нәкышь бүлеген тәмамлый (1955). 1956–67 елларда Казан сәнгать уч-щесендә укыта. 1967–2010 да Казан архит-ра-төзелеш ун-тында. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1964). Р. — 1960 еллар буынының әйдәп баручы осталарыннан берсе, хәзерге заман татар нәкышь мәктәбенең үсешенә булышлык итә. Реалистик сәнгать юнәлешендә уңышлы эшли, аны милли стилистика, респ-ка тормышыннан һәм аның үткәненнән образлар һәм сюжетлар б-н баета.










И.В.Рәфыйков. 1. «Кунакка». 1964. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. «И, туган тел!». 1988. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 3. «Болгар ханбикәсе». 1994. «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музее.



Мансур М. Рәфыйков.

Аерым әсәрләре («Нефтьче кыз портреты», 1959; «Кунакка», 1964; «Кызлар», 1964; «Җәлилчеләр», 1968; «Муса Җәлил», 1975) илебез сынлы сәнгатенең классик әсәрләреннән, алар совет һәм Россия нәкышь тарихына караган хезмәтләрдә репродукцияләнә. Портрет остасы буларак, Р. күренекле татар мәдәнияте эшлеклеләре, нефтьчеләр, төзүчеләр, спортчылар образлары галереясын тудыра («Гөлсем Болгарская», «М.Рахманкулова», икесе дә — 1957; «Җ.Фәйзи», 1959; «Авыл советы рәисе И.Мотыйгуллина», 1962; «Юл төзүчеләр», 1970; «Рапирачылар — Олимпия уеннары чемпионнары», 1978; «Г.Тукай», 1985; «Н.Даутов», «Автопортрет», икесе дә — 2003; «Таң йолдызы», 2004). Татар авылына багышланган картиналарында авыл кешеләренең истә калырлык образларын иҗат итә, крәстиян көнкүрешенең колоритлы мохитен сурәтли («Сыер савучылар», 1982; «Ана хәсрәте», 1984; «И, туган тел!», 1988; «Игеннәр өлгерде», 1999). Р. иҗатында индустриаль пейзаж («Яңа төзелешләр», 1970; «Нефть вышкалары», 1972; «Идел өстендә краннар» 1979) һәм табигать күренешләре (Идел һәм Кама, төрле ел фасылларында Идел буе табигате, авыл күренешләре: «Иске пристань», 1957; «Кама ярлары», 1963; «Алтын көз», 1980; «Туган авыл», 1989), юл этюдлары һәм картиналары (1969) әһәмиятле урын били. Натюрмортлар авторы. 1990 елларда татар тарихы темасын яктырта, ханбикәләр образларын иҗат итә («Болгар ханбикәсе», 1994; «Сөембикә тәхеттә», 1998; «Сөембикә-ханбикә», 1999). Казан һәм аның тирә-юнен, мәчетләр архит-расын («Болгар. Кече манара», «Кыш көне Әҗем мәчете күренеше», икесе дә — 1993; «Кремль һәм Кол Шәриф мәчете», 2004) сурәтли.

Респ-ка (1957 дән); зона — «Зур Идел» (1958 дән); бөтенроссия — Бөек Октябрь рев-циясенең 40 еллыгына (Мәскәү, 1957), «РСФСРның 16 автономияле республикасы» (Мәскәү, 1971); бөтенсоюз — «60 батырлык елы» (Мәскәү, 1978), «Туган илнең зәңгәр юллары», 1979); халыкара — «Спорт — тынычлык илчесе» (Мәскәү, 1980), «ГДР совет рәссамнары күзлегеннән» (Берлин, 1970); Казанның 1000 еллыгына багышланган (Мәскәү һәм С.-Петербург, 2005) күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда (1979, 1999, 2002, 2003, 2009, 2014), Әлмәттә (1980) уздырыла.

Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, Хәзерге заман сәнгате музеенда (Берлин), Татар акад. театрында, Татар опера һәм балет театрында, Әлмәттәге картиналар галереясында, «Nota Bene» шәхси галереясында (Мәскәү), чит илләрдәге шәхси тупланмаларда (Япония, Голландия, АКШ) саклана. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2002).

Ә с ә р.: Жизнь, прожитая в искусстве. К., 2005.

*Әд.:* В ә л и е в а - С ө л ә й м а н о в а Г. Иҗатка багышланган тормыш // Казан утлары. 1999. № 11; Ш а һ и е в а Р. Ана-ватан, җан-ватан җырчысы // Сөембикә. 2002. № 3; Искандер Рафиков: Родина. Человек. Героизм. К., 1995; Г о р н и к Г. Художник И.Рафиков // Казань. 1999. № 10.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**РӘФЫ́ЙКОВ** Мансур Миңнебай улы (8.12.1964, БАССРның Күгәрчен р-ны Күгәрчен а.), РФ Герое (20.1.1996), гв. подполковнигы. Казан югары командирлар танк уч-щесен (1986), Сов. Союзы маршалы Р.Я.Малиновский исем. бронетанк гаскәрләре хәрби академиясен (Мәскәү, 1999) тәмамлый. 1982 елдан Совет Армиясендә. Германиядәге Совет гаскәрләре төркемендә, Кавказ арты һәм Төньяк Кавказ хәрби округларында хезмәт итә. 1994–95 тә 20 нче гв. мотоукчы дивизиянең танк батальонында отделение командиры. Беренче Чечен кампаниясе вакытында батырлык күрсәтә (1994–96), Герой исеменә Чечен Респ-касы терр-ясендә конституцион стройны торгызу буенча хөкүмәт йөкләмәсен үтәгәне өчен лаек була. 1999–2000 дә Төньяк Кавказ хәрби округында 255 нче мотоукчы полк командиры урынбасары. 2001–05 тә Себер хәрби округында хезмәт итә. 2006 дан Калуга өлкәсе хәрби комиссары урынбасары. Батырлык, «Хәрби казанышлары өчен» орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* И в а н о в А.А. Герои Российской Федерации = Россия Федерациясе геройлары. К., 2012.

**РӘФЫ́ЙКОВ** Мәҗит Мәгъсүм улы (17.4.1925, БАССРның Зилаир кантоны — 24.1.1986, Казан), язучы, тәрҗемәче, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1985). Казан ун-тын тәмамлый (1956). 1956–65 елларда Татарстан китап нәшриятында тәрҗемәче һәм мөхәррир, «Совет әдәбияты» ж-лында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1966 дан әдәби иҗат б-н генә шөгыльләнә. Бөек Ватан сугышы елларыннан башкорт һәм татар матбугатында басылып килә. Шигырьләр, лирик хикәяләр, повестьлар һәм очерклар авторы («Илһам авазы», 1966; «Сиңа ничә яшь?», 1970; «Су башы», 1975; «Изге мизгелләр», 1985). Р.ның үз тәрҗемәсендә «Сандугач Хәбир чишмәсе» — «Родник Хабира-Соловья» (1972), «Ишкилде» — «Ишкильды» (М., 1975), «Үрдәге мәктәп» — «Школа на взгорке» (М., 1976) җыентыклары рус телендә басылып чыга. Р.ның әсәрләре тормыштан алып язылган, документаль характерда. Аның геройлары — яшьлекләре сугыш чорына туры килгән буын вәкилләре. Р. ш.у. әдәбият тарихына, татар поэзиясендә әдәби тәрҗемә мәсьәләләренә караган публицистик мәкаләләр авторы да. Рус теленә Г.Тукай, Ш.Камал, Н.Дәүли, М.Әмир, Х.Сәрьян, И.Гази, Ә.Еники әсәрләрен тәрҗемә итә. Бөек Ватан сугышында катнаша, медальләр б-н бүләкләнә. 1950 дә репрессияләнә, 1955 тә аклана.

*Әд.:* В ә л и - Б а р җ ы л ы М. Якты һәм җылы бөркелә... // Казан утлары. 2005. № 4.

**РӘФЫЙКОВ** Мәхасим Юныс улы (24.3.1927, БАССРның Илеш р-ны Черек-күл а. — 5.3.2006, Мәскәү), генерал-майор-инженер (1980), авиация генерал-майоры (1984), техник фән. канд. (1962), проф. (1991), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2001). Кызыл Армиянең Ленинград хәрби-һава академиясен (1952), проф. Н.Е.Жуковский исем. хәрби-һава инженерлары академиясен (Мәскәү, 1957) тәмамлый. 1945–49 елларда Кавказ арты хәрби округында: Югары командованиенең Резерв 9 нчы гв. артиллерия бригадасының 136 нчы округ запастагы укчы полкында өлкән писарь, Югары командование Резерв артиллериясенең 10 нчы гв. артиллерия дивизиясендә яшерен часть идарәсе башлыгы. 1950–51 дә СССР Хәрби-Һава Көчләре Баш командованиесенең Тәҗрибә һәм авиация техникасын серияләп төзү һәм хәрби кабул итү идарәсе органында Авиация техникасы ком-ты рәис-адъютанты. 1957–59 да Идел буе хәрби округында СССР Хәрби-Һава Көчләре фәнни-тикшеренү ин-тының Авиация кораллары сынау идарәсендә: баллистик сынаулар буенча әйдәп баручы инженер ярдәмчесе, авиаснарядлар баллистикасы буенча әйдәп баручы инженер. 1959–2006 да Н.Е.Жуковский исем. хәрби-һава инженерлары академиясендә, 1974–90 да ракета-артиллерия кораллары һәм сугышчан нәтиҗәлелек каф. башлыгы, 1991 дән профессоры. Р. яңа авиация техникасын тирәнтен тикшереп кулланууга кертә. Аның җитәкчелегендә академиядә яңа фәнни юнәлеш — авиация кораллары б-н идарә итү системасы оештырыла. Хезмәтләре авиация һәм космик техникаларны камилләштерүгә, ракета, авиация һәм бомбага тоту кораллары б-н идарә итү системасына карый. Механика буенча СССР МС Дәүләт бүләге лауреаты (1990). 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Авиационное артиллерийское вооружение. М., 1976; Системы управления бомбардировочным и ракетным вооружением. М., 1978 (автордаш); Ракетно-бомбардировочные установки и системы управления авиационным вооружением. М., 1990.

*М.З.Хәбибуллин.*

**РӘФЫ́ЙКОВ** Мәхмүт Мөхәммәтҗан улы (1.3.1924, Уфа), кинодокументалист, РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1992). Бөтенсоюз кинематография ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), «Моснаучфильм» (хәзер «Центрнаучфильм») киностудиясендә эшли. Атом-төш коралын, ракета техникасын, атом су асты көймәләрен һ.б.ны сынап карауга багышланган фильмнар төшерүдә катнаша. Яшерен төшерүләр барышында С.П.Королёв, И.В.Курчатов җитәкчелегендә эшли. Ю.Гагарин, А.Леонов, В.Терешкова һ.б. космонавтлар турында документаль фильмнар төшерә. Беренче космонавт Ю.Гагаринның җиргә әйләнеп кайту б-н үк Р. тарафыннан төшерелгән фотосурәтләре бөтен дөньяга тарала. Хезмәтләре: «Йолдызларга беренче рейс» («Первый рейс к звёздам», 1961), «Галәм күпере» («Космический мост», 1965) һ.б. 1 нче Халыкара балет конкурсы (Мәскәү, 1969), П.Чайковский исем. 3 нче Халыкара конкурс (Мәс-

кәү, 1966), В.Атлантов, М.Биешу, Э.Гилельс, М.Плисецкая, Д.Ойстрах, М.Ростропович һ.б. катнашкан постановкалар һәм концертлар турында фильмнар төшерә. Россия космонавтикасы тарихына зур өлеш керткән өчен Россия кинематография сәнгатьләре академиясенең «Ника» бүләге лауреаты (2011). Кызыл Йолдыз, БРның С.Юлаев исем. орденнары, медаль б-н бүләкләнә.

**РӘФЫ́ЙКОВ** Сәгыйт Рәүф улы (19.4.1912, Уфа губ., Бөре өязе Каеш а. — 19.1.1992, Мәскәү), химик-органик, химия фән. д-ры (1948), проф. (1951), Казакъстан ССР ФА академигы (1962), РФА мөхбир әгъзасы (1991; 1970 елдан СССР ФА мөхбир әгъзасы). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1937), Казанның С.М.Киров исем. 741 нче з-дында эшли. 1938–48 дә Органик химия ин-тында, 1954–66 да СССР ФАнең Элементорганик химия ин-тында (Мәскәү полимерлар тикшерү лаб-ясе мөдире); бер үк вакытта, 1944–48 дә, Мәскәү химия-технол. ин-тында. 1947–54 тә Казакъстан ССР ФАнең Химия фәннәре ин-тында нефть лаб-ясе мөдире, 1963–67 дә югары молекуляр кушылмалар бүлеге мөдире; бер үк вакытта Казакъстан а. х. ин-тында (1949–51, химия каф. мөдире) һәм Казакъстан ун-тында (1952–54, 1964–67). 1968–77 дә СССР ФАнең Башкортстан ф-лы Химия ин-ты директоры, 1968–84 тә ф-лның Президиумы рәисе (Уфа). 1984–91 дә СССР ФАнең Табигать фәннәре һәм техника тарихы ин-тында баш фәнни хезмәткәр (Мәскәү). Казакъстан ССР ФАнең Полимерлар химиясе буенча фәнни советы рәисе (Алма-Ата, 1960–68). Хезмәтләре химия, физик химия, мономерлар һәм полимерлар технологиясе өлкәләренә карый. Р., илдә беренче булып (акад. В.В.Коршак б-н бергә), гетерочылбырлы алифатик полиамидлар синтезлый һәм алардан үтә нык синтетик сүсләр алу мөмкинлеген күрсәтә. Сызыкча поликонденсациянең механизмын һәм кинетикасын ачыклый, полиамидлар, полиэфирлар, полиамидоэфирлар синтезын сурәтли. Ароматик карбон к-таларын һәм аларның кушылмаларын каталитик ачыту юлы б-н табу һәм алкилбензолны ачыткыч аммонолизлау алымнарын; газ фазасындагы мономерларны радиацион полимерлаштыру юлы б-н органик полимерлар яки нәорганик матдәләрнең каты өслекләренә ялганган сополимерлар алу ысулын таба. Эрүчән полимерларның җылыга чыдамлыгын күтәрә торган тотрыкландыру принцибын тәкъдим итә; җылылык һәм яктылык тәэсиреннән «үз-үзен саклый торган» югары молекуляр кушылмалар синтезлау алымын ача. Җылыга чыдам полимерлар — полиариленфталидлар синтезлау өлкәсендә яңа юнәлешне үстерә. Ирекле радикаллы полимерлаштыруны әверелешнең бик тирән дәрәҗәләрендә көйләү принципларын, зур ионоблокларда метилметакрилат һ.б. мономерларны көйләү һәм полимерлаштыру технологияләрен эшли. Каталитик системалар эшләүгә, гидрометаллургиядә, су әзерләү системасында, антибиотикларны аерып алу һәм чистартуда кулланыш тапкан алдан бирелгән үзлекле сумалалар һәм мембраналар синтезлауга, аларны тикшерүгә зур өлеш кертә.

Р. җитәкчелегендә үткәргеч торбаларны туфрак коррозиясеннән саклый торган нәтиҗәле пластикат-битум капламнар, махсус үзлекле органик пыялалар, сорбентлар һәм биологик актив кушылмалар булдырыла; нейтронга сизгер сцинтилляторлар һәм зур үлчәмнәрдәге яктылык фильтрлары алына, органик пыяладан зур габаритлы монолит блокларны сәнәгый җитештерү оештырыла. Илдә беренче полимерлар химиясе һәм физик химия дәреслекләре авторы. Уйлап табуга 150 дән артык авторлык таныклыгы бар. «Известия АН Казахской ССР. Серия химическая» ж-лының җаваплы мөхәррире (1950–56). БАССР (1968–72) һәм СССР ЮСлары (1974–83) депутаты. СССР МС (1983), РФАнең С.В.Лебедев исем. (1992, үлгәннән соң) бүләкләре лауреаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бер алтын һәм өч көмеш медале, Казакъстан ССР ЮСның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Введение к изучению высокомолекулярных соединений. М.–Л., 1946; Синтез и исследование высокомолекулярных соединений. М.–Л., 1949 (автордаш); Методы определения молекулярных весов высокомолекулярных соединений. М.–Л., 1963 (автордаш); Введение в физико-химию растворов полимеров. М., 1978 (автордаш).


*Әд.:* Сагид Рауфович Рафиков: Материалы к биобиблиогр. учёных Казахстана. А.-А., 1987; В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

*В.Г.Абзалова.*


**РӘФЫ́ЙКОВ** Сөббух Һади улы (15.7.1913, Уфа губ., Минзәлә өязе Нөркәй а. — 21.11.1971, Зәй штп), язучы. 1931 елдан «Колхоз газетасы» әдәби хезмәткәре, 1932 дән «Комбайн» Сарман район г-тасы мөхәррире урынбасары. 1934 тән Казанда: «Кызыл яшьләр» г-тасында бүлек мөдире, бер үк вакытта Татарстан китап нәшриятында мөхәррир булып эшли, Казан пед. ин-тында укый. 1937–47 дә Ерак Төньякка сөргенгә җибәрелә. Хөкем срогын тутыргач та аңа туган ягына кайтырга рөхсәт булмый, 1951 дә «элекке җинаятьләре өчен» кабат хөкемгә тартылып, Красноярск өлкәсенә гомерлек сөргенгә озатыла; 1956 да аклана. Сөргеннән кайткач, Зәй шәһәрендә төпләнә, 1961 гә кадәр «Социалистик Татарстан» г-тасының үзхәбәрчесе була. «Соңгы талпыну» (1932) һәм «Үсмерчак» (1937) — хикәяләр, «Ак төннәр» (1957) шигырьләр җыентыгы, «Беренче яз» (1962; 3 басма, 1979), «Авыл иртәсе» (1966), «Тын елга буенда» (1972) романнары авторы. Романнарында 1920–30 елларда татар авылы кичергән социаль үзгәрешләр, күмәк хуҗалыкка күчү процессындагы каршылыклар, производство мәсьәләләре тасвирлана. Соңгы романы Зәй гидростанциясен төзүчеләр тормышыннан.

*Әд.:* Ш ә р ә ф е т д и н о в Р. Чагыл тау сагына // Мәйдан. 2003. № 1.

**РӘФЫ́ЙКОВ** Хәбибрахман Габдрахман улы (18.8.1897, Казан — 27.12.1972, шунда ук), елга транспорты хезмәткәре, инженер-гидротехник, татарлардан беренче елга флоты



С.Р. Рәфыйков.



Ш.Х. Рәфыйков.


капитаны. Г.В.*Рәфыйковның* улы. Казан елга уч-щесен (1917), Ленинград елга транспорты инженерлары ин-тын (1933) тәмамлый. 1917–29 елларда елга судноларында эшли. 1930–35 тә Казан су транспорты идарәсендә инженер, плёс башлыгы, су төбен казу эшләре мөдире, баш инженер, бер үк вакытта, 1930–52 дә, Казан елга техникумында укыта, 1935–37 дә директор урынбасары. 1937 дә репрессияләнә (1940 та эш туктатыла). 1952–57 дә «Средневолжскстрой» берләшмәсенең 3 нче төзелеш идарәсе өлкән инженеры, Казан елга портының гидрокорылмаларын проектлау һәм төзү б-н шөгыльләнә.

*Әд.:* С а б и р о в Ф. Еллар һәм юллар // Казан утлары. 1977. № 9.

**РӘФЫ́ЙКОВ** Шәмсетдин Хөснетдин улы (12.9.1904, Оренбург губ., Актүбә өязе Григорьевка а. — 21.8.1972, Актүбә өлкәсенең Челкар ш.), Дан орденының тулы кавалеры (25.5.1944, 16.2.1945, 27.6.1945), сержант. Туган ягында эшли. 1941 елның июнь аеннан Кызыл Армия сафларында, августтан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 51 нче армиянең 1504 нче моторлаштырылган инженерлар батальонында отделение командиры, 110 нчы аерым моторлаштырылган штурмлау инженер-сапёрлар батальонында отделение командиры (13 нче армиянең 23 нче моторлаштырылган штурмлау инженер-сапёрлар бригадасы). 4 нче һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Мелитополь (1943), Кырым (1944) һәм Берлин (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 9 апрелендә Армянск шәһәреннән (Кырым) 25 *км* көнчыгыштарак сугыш операцияләрендә батырлык күрсәтә: отделение составында дошманның көчле уты астында мина кырлары һәм тимерчыбыклы киртәләр аша үтү юллары ясый, бу укчы подразделениеләргә дошманга каршы тоткарлыксыз һөҗүм итү мөмкинлеген бирә; 1945 нең 27–28 гыйнварында Люблин шәһәреннән 15 *км* көнчыгыштарак дошманның өзлексез көчле уты астында сапёрлар төркеме составында Одер елгасы аша салынган күперне төзәтә, контузия алса да, сугышчан бурычын үтәүне дәвам итә. 1945 нең 15 апреленнән 16 апреленә каршы төндә Нейсе елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: сугышчылар б-н елганы кичеп чыгып, мина кыры аша үтү юлы ясый, ут нокталарын юк итә; Р. җитәкчелегендә отделение паром кичүе ача. 1945 тә демобилизацияләнә. Челкар шәһәрендә яши. Геол. эзләнүләр экспедициясендә бригадир булып эшли. 1945 нең 24 ию-



Г.М.Рәхим.



Гәрәй Рәхим.

нендә Җиңү парадында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**РӘФЫ́ЙКОВА** Гөлнара Эрнст кызы (20.5.1975, Казан), тарихчы, тарих фән. канд. (2013), ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2011). Казан пед. ун-тын тәмамлый (1997). 1997 елдан «Гасырлар авазы — Эхо веков» ж-лы редакциясендә, баш мөхәррир урынбасары (2007 дән). Дәүләт бүләге «Гасырлар авазы — Эхо веков» журналы — Татарстан һәм татар халкы тарихын фәнни-документаль өйрәнү чыганагы» фәнни хезмәте өчен бирелә. 19 йөздә — 20 йөз башында Казан губернасында һәм Казанда хәйриячелек тарихын өйрәнүгә багышланган мәкаләләр авторы. Медаль б-н бүләкләнә.

**«РӘХӘ́Т»**, язгы арпа сорты. 1995 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты һәм Кара туфраклы булмаган зоналарның Үзәк р-ннары а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты б-н берлектә Э.Ф.Неттевич, В.П.Смолин, Л.М.Ерошенко, В.И.Чистякова, Л.М.Молчанова, Е.В.Кожемякин, В.И.Блохин тарафыннан гаплоидлы селекция алымы б-н чыгарыла. Куагының формасы тармаклану чорында аралы, бу чорда яфраклары төкләнми. Башак астындагы яфрагында антоциан төс бар, колакчыклары тешле, озын. Башагы цилиндрик, орчыксыман формада, саргылт төстә, уртача тыгызлыкта, ике рәтле. Өлгергәннән соң башагы туры тора яисә азрак бөгелгән була. Бөртеге озынча, бөртек төбендәге кылы озын төкле. Уртача өлгерешле, вегетация чоры 78–90 көн. Биеклеге 53–69 *см*, сөрлегүгә бирешми. Төрле типтагы туфракларда үсә. Уңыш бирүчәнлеге буенча югары генетик потенциалга ия, 1 *га* дан 60 *ц* уңыш алына. Тузан гөмбәсе б-н зарарланудан тотрыклылык гены саклый. Кыр шартларында őнчыл чык авыруына бирешми. Сыра ясау һәм бөртегенең сыйфаты буенча кыйммәтле сортлар исемлегенә кертелгән. 1000 бөртекнең авырлыгы 49–57 *г*, натура 700 *г/л* кадәр. Боткасының сыйфаты буенча югары баллга ия. Бу сорт РФнең Үзәк, Идел-Вятка һәм Урта Идел регионнарында, ш.и. Татарстанда чәчәргә рөхсәт ителә.

*Әд.:* Руководство по апробации сортовых посевов. К., 2002.

**РӘХИ́М** (Габдрәхимов) Гали Мөхәммәтшакир улы (4.11.1892, Казан — 3.3.1943), язучы, әдәбият галиме. Сәүдәгәрләр гаиләсеннән. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә (Казан) укый. Казан сәүдә уч-щесен (1913), Мәскәү сәүдә ин-тын (1917) тәмамлый, үзлегеннән гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнә. 1917 елдан соң Казанда яши, Хәрби-сәяси курсларда (1920–21) татар әдәбиятын, Шәрекъ академиясендә (1921–22), Шәрекъ пед. ин-тында (1922–30) татар әдәбияты һәм фольклоры тарихын укыта. 1909 да Р.нең география буенча «Җир йөзе» исемле беренче фәнни хезмәте басылып чыга. 1913–15 тә ул «Бикчәнтәй угылы» тәхәллүсе б-н «Ак юл» ж-лында балалар өчен хикәя һәм әкиятләрен бастыра. Соңыннан алар башлангыч сыйныфлар өчен дәреслекләргә кертелә, 1923 тә «Кызыл гөлләр» исеме б-н аерым китап булып чыгалар. 1913–15 тә «Аң» ж-лында аның өлкәннәр өчен хикәяләре басылып чыга («Галия», «Исемсез хикәя», «Сабирҗан хәзрәт»). Татар байлары тормышын көлеп тасвирлаган «Дача кайгысы» (1914) һәм «Җанвар» (1919) комедияләре, революциягә кадәрге татар зыялылары яшәешен күрсәткән «Идел» повесте (1921) авторы. «Татар әдәбияты тарихы» (1–2 т., 1923–27) китабы авторларының берсе. 1923–30 да Татар халкын өйрәнү фәнни җәмгыяте эшендә, фольклор экспедицияләрендә катнаша; татар теле һәм әдәбияты белеменә, фольклорына, тарихына, археографиясенә багышланган мәкаләләр авторы. 1931–34, 1938–40 та репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

Ә с ә р.: Халык әдәбиятымызга бер караш: Җырлар. К., 1915; Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре һәм йөзьеллык бәйрәм материаллары. К., 1926; Авылны өйрәнү: Татар авылларын монография ысулы белән өйрәнү өчен җентекле кулланма-программа. К., 1930; Сайланма әсәрләр. К., 2004.

*Әд.:* А з и з о в а - Х ө с н е т д и н о в а Г.А. Гали Рәхим — әдәбият тарихчысы. К., 2005; Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиогр. сүзлек. К., 2005; Гали Рәхим: Тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык. К., 2008.

**РӘХИ́М ГӘРӘ́Й** (псевд., чын исем-фамилиясе Родионов Григорий Васильевич) (15.7.1941, Шөгер р-ны Федотовка а., хәзер Лениногорск р-ны Аланлык а.), шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1986), РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (2007), ТРның халык язучысы (2011). Казан ун-тын (1967) һәм А.М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1981) тәмамлый. 1967 елдан «Татарстан яшьләре» г-тасында әдәби хезмәткәр, 1968 дән Татарстан китап нәшриятында балалар-яшүсмерләр әдәбияты бүлегендә мөхәррир. 1972–77 дә ТАССР Язучылар берлегендә әдәби консультант, 1978–79 да «Казан утлары» ж-лында проза бүлеге мөдире. 1979–87 дә Мәскәүдә: РСФСР Язучылар берлегендә милли әдәбиятлар буенча консультант, Урал һәм Идел буе төрки әдәбиятлар комиссиясенең җаваплы сәркәтибе. 1987–92 дә ТАССР Язучылар берлеге идарәсендә рәис урынбасары, «Шәһри Казан» г-тасы редакциясендә бүлек мөдире. 1992 дән ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр ком-тында (2007 дән ТРның 1нче классны дәүләт киңәшчесе). Әдәбиятка 1960 еллар уртасында килеп кергән Р.Г. халык җыры традицияләренә якын үзенчәлекле шигъри интонациясе, лирик кичерешләргә, фәлсәфи уйлануларга, шул ук вакытта публицистик яңгырашка һәм нечкә юморга корылган шигырьләре б-н җәлеп итә. «Вәгъдә» (1967), рус теленә тәрҗемәдә «Цветочная калитка» (М., 1973), «Зирекләрнең кара бөдрәләре» (1976), «Мәхәббәтем турында җыр» (1982), рус теленә тәрҗемәдә «Напевы курая» (М., 1983), «Моңнарым» (1987), «Үз җиремдә үз җырым» (1987), «Замандашларыма ачык хат» (1999), рус теленә тәрҗемәдә «Сабантуй моей мечты» (2003); балалар өчен «Чәчәк такыя» (1981), «Тимер торна» (1993) шигъри җыентыклар авторы. Р.Г.нең чәчмә әсәрләре, юмористик хикәяләре, публицистикасы «Көннәр язга авышкач» (1978), «Туган йортта» (1983), «Иптәшләр үзебезнеке» (1988), «Татлы сагышларым» (1991) җыентыкларына тупланган. М.Гафуриның «Кара йөзләр» әсәре буенча Б.Мөлековның «Каһәрләнгән мәхәббәт» операсына либретто (Татар опера һәм балет театрында 1981 дә куела; ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1984), төрки халыклар тарихын чагылдырган күп серияле «Борынгы Болгарны сагыну» («Сага древних Булгар», 2005) нәфис фильмының сценарий авторы. «Татар балалар поэзиясе антологиясе»н (1980), «Татар поэзиясе антологиясе»н (1–2 кит., 1992) төзүче, «Әдәбият энциклопедиясе сүзлеге»нең («Литературный энциклопедический словарь», М., 1987) татар һәм башкорт әдәбияты өлешләренең авторы. М.Львов, Д.Кәгелтдинов, Р.Бикбаев әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Әсәрләре рус, инглиз, немец, венгр һ.б. телләргә тәрҗемә ителә. ТАССР (1980), Литва ССР (1984), БР (1997) ЮС Президиумнарының Мактау грамоталары, медаль б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 2001–02; Птица радости: Стихотворения. М., 1986.

*Әд.:* Ф ә й з у л л и н Р. Нурлы һәм моңлы шигырьләр // Сайланма әсәрләр. К., 1998. Т. 4; Г а л и е в М. Чын исеме — Гөргери // Казан утлары. 2001. № 7; Ф и л и п п о в А. Гөргери // Казан утлары. 2006. № 3.

*Г.М.Габделхакова.*

**РӘХИ́М** (Рәхимов) Кәшиф Вәлиәхмәт улы (18.12.1905, Самара губ. Бөгелмә өязе, хәзерге Ютазы р-ны Бәйрәкә а. — 13.11.1989, шунда ук), язучы. Туган авылы мәдрәсәсендә укый. 1925 елдан Казанда яши. «Авыл яшьләре» ж-лы редакциясендә, Татарстан китап нәшриятында (1931–34) эшли. 1934 тә контрреволюцион эшчәнлектә гаепләнеп кулга алына, 5 елга сөргенгә сөрелә (1957 дә аклана). 1938 дән туган авылында яши, урта мәктәптә укыта. «Буразналар берләшкәндә» (1931) повесте, «Тозсызлар» (1932), «Шатлыклы көз» (1933) хикәяләр җыентыклары авторы.

*Ә.М.Шәрипов.*

**РӘХИМКУ́ЛОВ** Габдерахман Баһаветдин улы (12.5.1889, Уфа губ. Олы Каргалы а. — 15.10.1959, Мәскәү), сәясәт эшлеклесе, дипломат. «Мөхәммәдия» (Казан) мәдрәсәсендә укый, 1906 елда революцион хәрәкәттә катнашканы өчен аннан куыла. Дүртьеллык

Эстәрлетамак шәһәр уч-щесен тәмамлый (1910). 1910–15 тә Уфа губернасының Бишавыл-Унгар авылында земство мәктәбендә укытучы. Беренче бөтендөнья, Гражданнар, Бөек Ватан сугышларында катнаша. 1915 тә Россия армиясенә алына. 1916 да прапорщиклар мәктәбен тәмамлаганнан соң, Румын фронтына җибәрелә, взвод командиры. 1917 дә Көнбатыш фронтның 1 нче махсус армиясе мөселман сугышчыларының полк, дивизия, армия ком-тлары әгъзасы; Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтаенда (Мәскәү, 1917), Бөтенроссия мөселман гаскәриләрнең беренче корылтаенда (Казан, 1917) катнаша. 1917–18 дә Милләт Мәҗлесе эшендә катнаша. 1918–19 да Үзәк мөселман комис-тында эшли, Всеобуч оешмасының мөселман атлылары курслары комиссары. 1919–22 дә Эшче-крәстиян Кызыл армиясе Хәрби академиясендә укый. 1922–30 да Төркиядә дипломатик эштә. 1930 елларда Мәскәүдә Н.Нариманов исем. Шәрекъне өйрәнү ин-тында укыта, уку-укыту бүлеге мөдире, РСФСРның Главлит мөхәррире. 1938–42 дә шәрекъ телләре мөхәррире, СССР Главкинопрокатының кино базасы директоры. 1942 дән СССР Телеграф агентлыгы аппаратында эшли.

*М.Ф.Рәхимкулова.*

**РӘХИМКУ́ЛОВ** Габдулла Мөхәммәтгали улы (18.5.1926, Буа кантоны Иске Шәйморза а. — 11.10.1997, Казан, Чүпрәле р-ның Кече Шәйморза авылында җирләнә), җырчы, ТРның халык артисты (1996). 1954–62 елларда ТАССРның Җыр һәм бию ансамбле солисты, 1963–79 да Татар филармониясендә. Җырчы репертуарын халык җырлары, Татарстан композиторларының вокаль әсәрләре тәшкил итә (З.Хәбибуллин, С.Садыйкова, Ә.Бакиров, Р.Яхин әсәрләрен беренче башкаручы). Р. башкаруында С.Садыйкованың «Балкый Шәйморза утлары», «Зәңгәр төймә», «Керфегеңә тамармын мин» җырлары популярлык казана. Аның иҗаты үзенчәлекле булуы, төсмерләр байлыгы, татар муз. фольклоры нечкәлекләренә тирәнтен төшенүе б-н аерылып тора. Р. халыкчан җырлау традициясен саклау һәм үстерү юнәлешендә иҗат итә. Татар халкының борынгы озын көйләрен аеруча зур осталык б-н җиренә җиткереп башкара. Татарстан радио һәм телевидениесе аша чыгышлар ясый, грампластинкалар яздыра, актив концерт эшчәнлеге алып бара. Казанның бер урамы аның исемен йөртә.

*Әд.:* Б а т т а л Ф. Онытырлык түгел аны // Сәхнә. 2011. № 7; С ә й ф у л л и н Р. Халкыбызның үз җырчысы // Халыкка багышланган тормыш. К., 2012. *Ф.Ш.Салитова.*

**РӘХИМКУ́ЛОВА** Мәдинә Фәтхи кызы (30.6.1916, Уфа губ. Олы Каргалы а. — 15.2.2004, С.-Петербург), төбәк тарихчысы, педагог. Казан ун-тында укый, Оренбург пед. ин-тын тәмамлый (1942). 1929–32 елларда Дәүләкән элеваторында (БАССР) төрле эшләр башкара, бер үк вакытта җидееллык фабрика-завод мәктәбендә укый. 1932–36 да Кыргызстан АССРда башлангыч мәктәп мөдире. 1936–38 дә «Үзтранс» автобазасында эшли, бер үк вакытта Сәмәрканд рабфагында укый. 1943–53 тә Оренбург шәһәре һәм Оренбург өлкәсе мәктәпләрендә, 1953–71 дә Оренбург а.х. ин-тында укыта. Хезмәтләре татар, башкорт мәгарифе һәм мәдәнияте тарихына карый. СССР Геогр. җәмгыяте әгъзасы (1952 дән).

Х е з м.: Медресе «Хусаиния» в Оренбурге. Оренбург, 1997; Преподавание естественных наук в татарских школах дореволюционной России. Оренбург, 1998. *М.А.Сәйдәшева.*

**РӘХИ́МОВ** Бакый Сибгатулла улы (1913, Казан губ., Казан өязе Түбән Кенә а. — 3.3.1940, Выборг култыгындагы Вихревой утравында, туганнар каберлегенә җирләнә), Сов. Союзы Герое (21.3.1940, үлгәннән соң), рядовой. Фабрика-завод уч-щесен тәмамлаганнан соң, Казанның В.В.Куйбышев исем. киноплёнка ф-касында (соңрак «Тасма» ҖБ) эшли. 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша, 109 нчы разведка батальонында пулемётчы (Төньяк-Көнбатыш фронтта 7 нче армиянең 86 нчы мотоукчы дивизиясе). Койвисто-Бьёркё утравы янындагы сугышта батырлык күрсәтә: 1940 ның 22 февралендә разведка төркеме составында тимерчыбыклы киртә аша юл ясап, Р. дошманның 2 ут ноктасын ала; яралана, әмма сафта кала. 1940 ның 3 нче мартындагы бәрелештә һәлак була. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә. Туган авылында Р.га — һәйкәл, «Тасма» ҖБ бинасында мемориаль такта куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

**РӘХИ́МОВ** Гаптелфәрит Әхмәтгәрәй улы (19.5.1925, Буа кантоны (хәзер Апас р-ны) Болын-Балыкчы а. — 16.3.1997, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1983). Болын-Балыкчы җидееллык мәктәбен тәмамлый (1943). 1950–88 елларда Апас р-нында: Чапаев исем. к-зда баш хисапчы (1954 кә кадәр), Болын-Балыкчы авыл советы рәисе (1957 гә кадәр), «Ракета» к-зы рәисе (1988 гә кадәр). Җитештерүдәге уңышлары өчен колхоз дүрт тапкыр КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның күчмә Кызыл Байрагы б-н бүләкләнә; Р. СССР ВДНХсының Мактау тактасына, Мактау китабына кертелгән. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Октябрь Рев-циясе, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**РӘХИ́МОВ** Җәмит Гата улы (13.1.1935, Шөгер (хәзер Лениногорск) р-ны Иске Шөгер а. — 27.12.1996, шунда ук), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1985). Казан ун-тын тәмамлый (1961). 1953 елдан Әлмәт нефть эшкәртү пр-тиеләрендә оператор һәм электромонтёр булып эшли, 1959–60 та — «Заветы Ильича» Лениногорск район г-тасында а.х. һәм сәнәгать бүлеге мөдире. Лениногорск нефть техникумын тәмамлаганнан соң (1970), скважиналарны капиталь ремонтлау идарәсендә мастер, нефть эшкәртү пр-тиеләрендә инженер. Әдәбиятка 1950 елларда килә. «Алтын яткан җирләрдә» (1966), «Кобзарь — Тукай кунагы» (1968), «Якташларым» (1972), «Батырлык чакрымнары» (1976) очерклар җыентыклары хезмәт кешесенә багышлана. «Девон хәбәрчесе» (1977), «Өлешемә тигән көмешем» (1978), «Тәвәккәл таш яра» (1981), «Кыядагы чәчәкләр» (1989), «Сагыш» (1991) повестьларында нефтьчеләрнең авыр хезмәте, катлаулы язмышлары бәян ителә. Бай тарихи материалларга нигезләнеп психологик планда язылган «Батырша» романында (1992) 18 йөз уртасында татар һәм башкорт халкының патша хөкүмәтенә каршы баш күтәрүе, җитәкчеләре, милли азатлык хәрәкәте идеологы Абдулла Алиевның (Батыршаның) каһарманлыгы, шул чор халкының гореф-гадәтләре, төрле катлау кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр тасвирлана. Бу роман 20 йөз татар милли әдәбиятының тарихи роман жанрында язылган күренекле әсәрләреннән санала.



Г.М. Рәхимкулов.



Б.С. Рәхимов.

*Әд.:* Т ө х ф ә т у л л и н Р. Кыядагы чәчәкләр // Казан утлары. 1995. № 1.

**РӘХИ́МОВ** Илгизәр Ильяс улы (16.4.1956, Казан), зоолог, биол. фән. д-ры (2002), проф. (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1982), шунда ук эшли. 1986 елдан Татар гуманитар-пед. ун-тында, биоэкология каф. мөдире (2002 дән). Хезмәтләре орнитология, экология, экологик белемгә карый. Р. Урта Идел буе кошлар синантропизациясенең (кеше янында яшәүгә яраклашу) төп кагыйдәләрен эшли, төбәк фаунистикасын һәм Татарстан шәһәрләрендә хайваннар экологиясен өйрәнүгә өлеш кертә. «ТРның Кызыл китабы»н төзүдә (2006) катнаша. «Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы» («Растительный и животный мир Татарстана», 2006) уку ярдәмлеге автордашы. Россиянең Кошларны саклау берлеге рәисе (1992 дән).

Х е з м.: Птицы городов Среднего Поволжья и Предуралья. К., 2001; Авифауна Среднего Поволжья в условиях антропогенной трансформации естественных природных ландшафтов. К., 2003; Адаптивные особенности сизого голубя (Columba livia) в условиях урбанизированной среды (на примере города Казани). К., 2008 (автордаш); Птицы городов России. М.–СПб., 2012.

**РӘХИ́МОВ** Камил Йосыф улы (25.8.1900, Севастополь ш. — 25.2.1978, Уфа ш.), композитор, фольклорчы, БАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1969). 1928 елда Башкорт сәнгать техникумының тынлы уен кораллары бүлеген тәмамлый. 1929–30 да Башкорт драма театрының музыка бүлеге мөдире, 1930–38 дә, 1945–47 дә Башкорт радиосында муз. тапшырулар мөхәррире, 1943–45 тә

Уфа гарнизонының хәрби оркестры музыканты, 1945–69 да БАССР Мәдәният министрлыгының Сәнгать эшләре идарәсе каршындагы фольклор кабинеты фәнни хезмәткәре. Композиторлар берлеге әгъзасы (1943). Р. татар һәм башкорт муз. фольклорын туплау һәм эшкәртү б-н шөгыльләнә. 400 гә якын башкорт, татар һәм рус халык көйләренең үрнәкләрен нотага сала. БАССРның гомуми белем мәктәпләре өчен музыка буенча беренче уку әсбаплары авторы. Төп әсәрләре: башкорт халык көйләре «Ашҡаҙар» һәм «Перовский» (оркестр өчен), «Салават» һәм «Бейеш» (хор һәм оркестр өчен), «Сандуғач» һәм «Зөлхижә»гә (оркестр б-н тавыш өчен) эшкәртмәләр; М.Бурангуловның «Башкорт туе», Д.Юлтыйның «Карагол», А.Таһировның «Үрнәк» әсәрләре буенча спектакльләргә муз. бизәлеш; «С.Сәйдәшев темасына Шәрекъ маршы», «Башҡорт маршы»; симфоник һәм тынлы оркестр өчен пьесалар; башкорт һәм татар шагыйрьләре шигырьләренә хор җырлары, җырлар һәм романслар һ.б.

*Әд.:* Композиторы Башкирии: Краткий биогр. сб. Уфа, 1982.

**РӘХИ́МОВ** Равил Зөфәр улы (11.5.1938, Таҗикстан ССРның Күкташ р-ны Күкташ пос.), төзелеш материаллары өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1985), Россия Архит-ра һәм төзелеш фәннәре академиясенең мөхбир әгъзасы (1993), ТССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1991), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2007), Россиянең атказ. төзүчесе (2002). 1961 елда Казан төзелеш инженерлары ин-тын (хәзер Казан архит.-төзелеш ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (бүленеп: 1961–64 елларда «Куйбышевгидрострой» оешмасында), проректор (1976–89), төзелеш материаллары каф. мөдире (1989 дан), проф. (1986). Хезмәтләре төзелеш материаллары җитештерү максатында җирле чимал ресурсларын өйрәнүгә; файдалы материаллар булдыру һәм үзлекләрен өйрәнүгә; төрле кулланылыш шартларында композицион материалларның чыдамлыгын тикшерү һәм фаразлауга карый. Р. җитәкчелегендә метрополитен туннельләренең бөжра блокларын әзерләү өчен су үткәрми торган югары чыдамлы бетоннар һәм комплектлау материалларының составлары эшләнә (аларны җитештерү технологияләре Казан з-дларында үзләштерелә). Р.ның тәкъдимнәре һәм эшкәртмәләре нигезендә респ-када йомшак түбә ябу материаллары («Нижнекамсккровля» АҖ) һәм декоратив бизәкләү измәләре («Полимерстрой» АҖ, Алабуга ш.) җитештерү җайга салына. Р. җитәкләгән коллектив ТР МКның респ-када төзелеш индустриясе базасын камилләштерү, җирле чималдан рациональ файдалану, төзелеш материаллары сәнәгатенең җитештерү көчләрен үстерү һәм урнаштыру турындагы күп кенә карарларын әзерләү барышында тәкъдимнәр кертә. Уйлап табуга 31 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995). Медальләр б-н бүләкләнә. РФнең атказ. югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (1998).

Х е з м.: Современные кровельные материалы. К., 2001 (автордаш); Ресурсо- и энергосбережение в строительстве и жилищно-коммунальном хозяйстве // Архитектура и строительство Москвы. 2003. № 2–3; Современные теплоизоляционные материалы. К., 2006 (автордаш); Строительные материалы. М., 2007 (автордаш).

**РӘХИ́МОВ** Рәис Сәетгали улы (24.2.1942, БАССРның Аскын р-ны Билгеш а.), а. х. җитештерүен механикалаштыру өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1990), проф. (1992), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2003). 1965 елда Чиләбе авыл хуҗалыгын механикалаштыру һәм электрлаштыру ин-тын тәмамлаганан соң, БАССРның «Төй» с-зында эшли. 1968 дән Чиләбе аграр ун-тында, туфрак эшкәртү һәм чәчү машиналары каф. мөдире (1993 тән), проректор (2002–08), бер үк вакытта, 2002–05 тә, Урал а.х. техникасын сынау үзәге директоры (Чиләбе ш.). Хезмәтләре туфрак эшкәртү һәм а.х. культураларын чәчү өчен техник чараларның конструктив схемаларын һәм параметрларын эшләүгә карый. Р. җитәкчелегендә туфракны һәм чәчүлекләрне төп һәм чәчү алды эшкәртүләре өчен 50 дән артык универсаль машина эшләнеп, сынауга һәм җитештерүгә куела. Уйлап табуга 17 патенты бар.

Х е з м.: Машины для интенсификации основной обработки почвы. Челябинск, 1988 (автордаш); Элементы системы автоматизированного проектирования широкозахватных почвообрабатывающих машин. Челябинск, 1988 (автордаш); Практикум по сельскохозяйственным машинам. М., 1997 (автордаш); Ресурсосберегающая техника для возделывания зерновых культур . М., 2007.

**РӘХИ́МОВ** Ринат Рәхим улы (17.3.1939, Арча р-ны Урта Сәрдә а. — 16.8.1984, шунда ук), шагыйрь. Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), Питрәч р-ны Ильич исем. к-зда агроном, 1965 елдан рәисе булып эшли. 1973–84 тә шул ук районның а.х. идарәсендә баш агроном-мелиоратор, мелиорация берләшмәсенең баш агрономы, соңрак аның рәисе. «Тормыш атомнары» (1964), «Сабан тургае» (1965), «Туган җирем» (1970), рус теленә тәрҗемәдә «Тепло земли» (1972) җыентыклары авторы. Иҗатының үзәгендә гражданлык лирикасы өстенлек итә. Шигырьләрендә авыл кешесенең хис-тойгылары, табигать күренешләре оста тасвирлана.

*Әд.:* Х ә к и м С. Җир шагыйре // Казан утлары. 1971. № 9.

**РӘХИ́МОВА** Бикә (псевд., чын исем-фамилиясе Фәйзуллина Миннебикә Рәхмәтулла кызы) (10.4.1939, Әлки р-ны Чуаш Кичүе а. — 9.3.2011, Казан, туган авылында җирләнә), шагыйрә. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1963), СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында эшли. 1973 тән Казан мәктәпләрендә татар теле укыта. 1980–94 тә Татарстан китап нәшриятында әдәби басмалар мөхәррире. «Сәрвиназ» (1986), «Ачыл, күңел!» (1989), «Иделләр казанында» (1999), «Мәрхәмәт» (2005), балалар өчен «Кырмыскалар өендә» (1991), «Урман радиосы» (1995), «Җайдак малай» (2007) шигырь җыентыклары, «Бакый сагыш» (2009) публицистика китабы авторы. Р.ның иҗаты фәлсәфи мотивларга, халыкның яшәеше турында лирик уйлануларга бай. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә (1994). ТР Язучылар берлегенең А.Алиш исем. бүләге лауреаты (2009).

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**РӘХИ́МОВА** Рәсимә Миңнәхмәт кызы (12.9.1956, Ютазы р-ны Урыссу штп), социолог, филос. фән. канд. (1993), социол. фән. д-ры (2002), проф. (2006), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2005). Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлаганнан соң (1980), Әлмәт нефть ин-тында, гуманитар белем һәм социол. каф. мөдире (1998 дән), проректор (2000 нән). Хезмәтләре милләтара мөнәсәбәтләр, яшьләр проблемаларына карый.

Х е з м.: Особенности социализации и ресоциализации провинциальной городской молодёжи в постсоветском российском обществе (на материале Республики Татарстан). К., 2001; Девиантные практики провинциальной молодёжи // Социальные проблемы переходного российского общества. К., 2002.


**РӘХИМУ́ЛЛИН** Ирнис Әхмәдулла улы (3.2.1942, Казан), хор дирижёры, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1987). Казан музыка уч-щесен (1962), Казан консерваториясен (1970) тәмамлый. 1968 елдан Казан ун-тының Татар халык хоры җитәкчесе. Бер үк вакытта, 1970–85 тә, Казан консерваториясенең хор дирижёрлыгы кафедрасында укыта, 1975–2002 дә Татар опера һәм балет театрында хормейстер (1982–85 тә баш хормейстер). 1995–2005 тә Татар гуманитар ин-тында татар хоры җитәкчесе; ш.у. Казан мәктәпләрендә балалар хорлары б-н дә эшли. Балалар һәм яшьләр хор коллективларын оештыручы һәм җитәкчесе буларак, Р. хор б-н чыгыш ясауның проф. үсешенә зур өлеш кертә.

*Әд.:* Золотое яблоко Ирниса-абый // Казань. 2012. № 11.

**РӘХИМУ́ЛЛИН** Райнур Рәхимулла улы (15.2.1941, Кукмара р-ны Зур Кукмара а.), галим агроном, ТАССРның атказ. агрономы (1983). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1969). 1958–2001 елларда Кукмара р-нында механизатор, 21 нче партсъезд исем. к-зда баш агроном, район а.х. идарәсенең игенчелек бүлеге башлыгы (1970 тән). Р. җитәкчелегендә район хуҗалыкларында игенчелек һәм үсемлекчелек алга китә; бөртекле ашлык уңышы 1 *га* дан 1970 тә — 13,8 *ц*, 1991–95 тә уртача — 23,4 *ц*, 1996–2000 дә — 24,9, 2001 дә 37 *ц* тәшкил итә. Медаль б-н бүләкләнә.

**РӘХМӘ́Т** (Рәхмәтуллин) Бари (Габделбари) Сибгатулла улы (29.5.1897, Урал губ., Гурьев өязе Жилая Коса а. — 26.5.1957, Мәскәү, Казанда җирләнә), шагыйрь. Башлангыч белемне туган авылы мәдрәсәсендә ала. 1919 елдан Казанда: «Кызыл Армия» г-тасында әдәбият бүлеге мөдире, бер үк вакытта «Эш», «Эшче», «Кызыл Шәрекъ» г-таларында үзенең сатирик әсәрләрен бастыра. 1921 дән туган якларына кайтып китә. 1932 дән кабат Казанда, 1939 га кадәр бухгалтер булып эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша, «Совет сугышчысы» г-тасында хәрби хәбәрче була. Балалар өчен «Кем көчле?» (1949), «Нәниләр китабы» (1953), «Иң күңелле чак» (1957; 2 басма 1997), «Сабан туенда»

(1953; русчага тәрҗемәсе «На Сабантуе», 1958), «Сөенеч» (1972), «Сара мәктәпкә бара» (2007) шигырь җыентыклары авторы. Р.нең шигырьләре форма җыйнаклыгы, фикер һәм хиснең балалар рухына ярашлы, табигый, көчле яңгырашлы булулары б-н аерылалар.


Б.С. Рәхмәт.

*Әд.:* Кукушкин Р. Канатлы дөнья. К., 1984.

**РӘХМӘТУЛЛА́ АЛАНЫ́** посёлогы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 35 *км* көнбатыштарак, Казан — Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 61 кеше (татарлар) яши. Урман хуҗалыгы; агач эшкәртү цехы. 1920 елларда нигез салына. Беренче исеме — Яңа Алабуга. Оештырылган көннән ТАССР-ның Мамадыш кантоны Түбән Сон волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 56, 1970 тә — 60, 1979 да — 91, 1989 да — 78, 2002 дә — 72 кеше.

**РӘХМӘТУЛЛА́ЕВ** Марат Алим улы (15.9.1956, Үзбәкстан ССРның Ташкент өлкәсе Ахангаран р-ны Куйбышев а.), мәгълүмат технологияләре өлкәсе белгече, техник фән. д-ры (1995), проф. (2006). 1978 елда Ташкент политехник ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1996–98 елларда Үзбәкстан Респ-касы Фән һәм техника буенча дәүләт ком-тының Мәгълүмат технологияләре үзәге директоры урынбасары, 1998–2000 дә Тышкы икътисади багланышлар департаменты директоры. 2000 нән Китапханәләр ассоциациясенең башкаручы директоры, бер үк вакытта, 2004 тән, Үзбәкстан Респ-касы Милли китапханәсенең бүлек мөдире, Ташкент мәдәният ин-ты һәм Ташкент мәгълүмат технологияләре ун-ты профессоры. Р. — җитештерү б-н автоматлаштырылган идарә итү системалары, медицина, машиналар төзелеше, металлургия өчен эксперт системалары төзү, компьютер лингвистикасы, электрон китапханәләр һәм китапханәләр челтәре буенча проектлар авторы һәм аларның җитәкчесе. «Компьютер-Азия» фәнни-популяр ж-лының баш мөхәррире (1994–96). «Дуслык» ордены б-н бүләкләнә.

Хезм.: Композиционная модель соответствий для решения задач нечёткой технологической среды // Автоматика и вычислительная техника / Латвийская АН. 1993. № 6; Информационные технологии в библиотеках. Таш., 2003; Advanced Information Library Infrastructure: As in Important Social Tool for the Prevention of Crisis Situations in Central Asia // Library Hi Tech News. 2002. V. 19, № 9.

**РӘХМӘТУ́ЛЛИН** Әхмәтҗан Фазлулла улы (1832–1910, Казан), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре (1874), җәмәгать эшлеклесе. Сембер губернасының Буа өязе крәстияннәре нәселеннән. 1852 елда чәй һәм шикәр б-н сәүдә итү фирмасы ача. 1869 да Казан сәүдәгәрләре хисабына кертелә. Казан шәһәр думасы гласные (1871–87), Үзара кредит җәмгыяте идарәсе әгъзасы. *«Мәрҗания», «Касыймия»* мәдрәсәләренең яңа биналарын төзүдә башлап йөрүче һәм җәмәгать идарәчесе.

*Р.Р.Салихов.*

**РӘХМӘТУ́ЛЛИН** Гали (1759, фаразланганча, Чистай өязе — 1834 тән соң), хәреф җыючы, Россиядә Шәрекъ басмаларының беренче осталарыннан. 1780 елда рекрутлыкка бирелә, Балтыйк флоты корабльләрендә матрос булып хезмәт итә. 1790–91 дә Рус-швед сугышында катнаша, ике медаль б-н бүләкләнә. 1791 нең 25 декабрендә Екатерина II Фәрманы б-н Петербургта *Азия басмаханәсендә* хәреф җыючы итеп билгеләнә, 1800 дә Казандагы *Азия басмаханәсенә* күчерелә. 25 еллык солдат хезмәтен тәмамлагач, үз иреге б-н ялланып эшли. 1829 да Азия басмаханәсе Казан ун-ты басмаханәсе б-н берләштерелә (Р. 1815 тән берьюлы ике урында эшли). 1834 тә картлык буенча эштән азат ителә. Тырышлыгы өчен берничә тапкыр акчалата бүләкләнә. Р.га класслы чин бирү турында үзенең һәм Казан уку-укыту округы попечителенең күпсанлы үтенеч язулары юк-бар сылтаулар б-н кире кагыла. Эшләү дәверендә Р. тарафыннан Казандагы татар басмаханәләренең барлык басмалары һәм ун-т басмаханәсенең гарәп шрифтындагы басмалары дөнья күрә («Әттәхият», «Һәфтияк», «Кыйссаи-Сәйфелмөлек» һ.б.). Р. ун-т басмаханәсенең беренче хәреф җыючыларын, ш.и. русларны да өйрәтә.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. У истоков татарской книги. К., 1992.

**РӘХМӘТУ́ЛЛИН** (Рәхмәти) Дефак Гатаулла улы (8.2.1951, Бөгелмә р-ны Татар Димскәе а. — 7.4.2007, Бөгелмә ш.), нәкышьче, монументалист, гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы. Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый (1975). ТР Сәнгать фондының Бөгелмә бүлегендә эшли (1976–95). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1991). Татар гамәли бизәлеш сәнгате өлкәсендә әйдәп баручы рәссамнардан берсе, станлы нәкышь остасы. Иҗат юлын үзенчәлекле форма, символик эчтәлеккә ия, ачык, үзенә бер милли төсмерле, еш кына борынгы төрки гореф-гадәтләргә нигезләнгән пейзажлар, портретлар, тематик картиналар иҗат итүдән башлый: «Август. Көнбагышлар» (1976), «Атилла энисе белән» (1980), «Тургай җыры» (1982), «Каз канаты» (1983), «Орлыклар (Роза портреты)» (1984), «Иртәнге намаз», «Малевич белән тәнге бәхәс», «Безнең чибәркәй» (барысы да — 1990), «Гөлгәмеш», «Яфәс» һәм «Алтынчәч» триптихы (1993), «Корбан бәйрәме» (2001), «Казан капкалары, яки Алтынчәчнең кайтуы» (2006). 1970 еллар ахырында Р. хәзерге заман интерьерларында киез куллануның яңа мөмкинлекләрен ача. Хатыны Р.Рәхмәтуллина б-н бергә татар киез келәмнәре эшләүне яңартып җибәрә (к. *Киез*). Борынгы «ала киез», «сырмак» технологияләрен өйрәнә. Халык осталарыннан, ш.и. туган авылында яшәүче осталардан бизәү ысулларын үзләштерә. Киезне яңача бизәкле, төсле композицияләр б-н баета, дивар келәм-панносының шартлы сурәтләр һәм бизәкләр рәвешендәге тематик сюжетларга корылган яңа төрен иҗат итә. Р.ның аеруча әһәмиятле әсәрләреннән «Сабан туе» (1980), «Шүрәле» (1982), «Дуслыкка гимн» (1982), «Кубыз», «Кама», «Айлы төн» (Г.Тукай әкиятләре буенча) (барысы да 1983), «Тормыш агачы» (1984), «Карга боткасы» (1989), «Иң әүвәл сүз булган» (1990), «Скиф моңнары» (1991), «Чәчәк ат, Татарстаным» (2002), «Кояшлы келәм» (2007) дивар келәмнәрен күрсәтергә була. Р.Рәхмәтуллина б-н берлектә киез намазлыклар һәм идән келәмнәре суга.


Д.Г. Рәхмәтуллин. «Атилла энисе белән». 1980.


Д.Г. Рәхмәтуллин. «Җиз самовар». 1983.


Д.Г. Рәхмәтуллин. «Чагылыш». Киез. Сырмак. 2002.

1980 елларда рәссам Б.Ш.Мәрданов б-н автордашлыкта җәмәгать биналары интерьерлары өчен дивар бизәкләре (Бөгелмә шәһәрендәге 8 нче мәктәп интерьерында «Кояшлы алан»; Әлмәттәге сәүдә техникумы интерьерында «Әлмәт туфрагында»; Бөгелмә драма театры фойесында «Без — сәйяр артистлар»); хатыны Р.Рәхмәтуллина б-н берлектә «Туган шәһәрем иртәсе» (1986, шәһәр

советы бинасы); «Мәңгелек яз» (1988, Бөгелмәдәге 5 нче төзелеш тресты тулай торагы) гобеленнары иҗат итә. Бөгелмәнең 200 еллыгы хөрмәтенә (1980), Бөгелмәдәге 352 нче дивизия истәлегенә (1985) монумент эскизлары авторы. Бөгелмәнең яңа гербын (1981), юбилей медальләрен һәм күкрәк тамгаларын эшли. Гомеренең соңгы елларында борынгы төркиләр тарихы һәм мифологиясе өлкәсендә эзләнүләр алып бара.

Респ-ка (1977 дән); зона — «Зур Идел» (1980, 1985, 1991, 2003, 2004); бөтенроссия — «Россиянең зәңгәр киңлекләре» (Ленинград, 1984), «16 автономияле республика» (Мәскәү, 1989) күргәзмәләрендә; «Татарт» бөтентатар күргәзмәсендә (С.-Петербург — Казан, 1991); Мәскәүдәге «Олимпиада-80» халыкара плакат конкурсында катнаша. Шәхси күргәзмәләре: 1980 (Казан, Б.Ш.Мәрданов б-н берлектә), 1990 (Уфа), 2003 (Казан).

Әсәрләре Дәүләт Шәрекъ халыклары сәнгате музеенда (Мәскәү), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, «Шәрекъ» традицион һәм хәзерге заман сәнгате фондында (Уфа), ТР Милли музеенда, Яшел Үзәндәге Халык иҗаты һәм көнкүреше музеенда саклана.

Х е з м.: Дети Атлантиды. К., 1999; Крылатый змей. Бугульма, 1999.

*Әд.:* В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995; К а м а л Г. Киез келәм — кояз келәм // Сөембикә. 2001. № 12.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**РӘХМӘТУ́ЛЛИН** Зариф Садыйк улы (1872, Вятка губ., Сарапул өязе Воткинск з-ды посёлогы — 1943, Казан), педагог. Хезмәт Герое (1928). Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлаганнан соң (1892), рус-татар уч-щеләрендә эшли: Сембер губернасының Кормыш өязе Яңа Мөчәли авылында, 1893 елдан Вятка губернасының Сарапул өязе Әгерҗе авылында, 1903 тән Вятка губернасының Малмыж шәһәрендә, 1908 дән Чистайда. Малмыж һәм Чистайда Р. башлангычы б-н рус-татар уч-щеләре биналары төзелә, алар хәзер дә файдаланылалар. 1918 дән ТАССР һәм Казан губернасы мәгариф органнарында. 1921–25 тә Казан татар пед. техникумында директор. Милли пед. кадрлар әзерләүнең совет системасын булдыруда мөһим роль уйный.

*Әд.:* Герои Труда Татарии. 1920–1938 гг.: Док. очерки. К., 1974.

**РӘХМӘТУ́ЛЛИН** Зикрулла Хәйрулла улы (1901, Ташкент — 1971, Үзбәкстан ССР, Сәмәрканд ш.), гистолог, мед. фән. д-ры (1939), проф. (1940). Урта Азия ун-тының (Ташкент) мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1928), шунда ук, тире-венерология клиникасында, бер үк вакытта нормаль анатомия һәм эмбриология кафедрасында эшли. 1936 елдан Ташкент мед. ин-тында, 1939 дан гистология каф. мөдире. 1945 тән Кашкадарья өлкә сәламәтлек саклау бүлеге мөдире урынбасары. 1946–70 елларда Сәмәрканд мед. ун-тының һәм бер үк вакытта, 1946–54 тә, Сәмәрканд а.х. ин-тының гистология кафедралары мөдире. Хезмәтләре периферик нерв системасы морфологиясенә карый. Бөтенсоюз анатомнар, гистологлар һәм эмбриологлар җәмгыятенең Сәмәрканд бүлеге рәисе (1957). Медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Зикрулла Хайруллович Рахматуллин (к 60-летию со дня рождения и 35-летию научно-педагогической и общественной деятельности) // Архив анатомии, гистологии и эмбриологии. 1962. Вып. № 7.

**РӘХМӘТУ́ЛЛИН** Ирек Мәхмүт улы (11.4.1928, Казан — 18.05.2013, шунда ук), патофизиолог, мед. фән. д-ры (1966), проф. (1968), ТАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1978, 1998). А.Д.Адо шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), шунда ук, патофизиология кафедрасында эшли. 1967 елдан Казан ГИДУВы проректоры, ректоры (1968). 1978 дән Казан мед. ин-тында (1994 тән Казан мед. ун-ты), патофизиология каф. мөдире (1978–93), проф.-консультант (1993–99). Хезмәтләре организмда аллергик үзгәрешләр барышында төрле әгъзалар һәм системаларның үзгәрү механизмнарын өйрәнүгә карый. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы бар. Бөтенсоюз патофизиологлар җәмгыятенең Казан бүлеге рәисе (1978–98). «Аллергик реакцияләрнең күзәнәк һәм молекуляр механизмнары» («Клеточные и молекулярные механизмы аллергических реакций») хезмәтләре сериясе өчен ТР ФАнең А.Д.Адо исем. бүләге бирелә (2003). «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К аллергической реакции скелетной мышцы. М., 1963; Интенсивная терапия в клинической практике. Л., 1976; Современные аспекты рентгенодиагностики. Л., 1977; Рахит и рахитоподобные заболевания. Л., 1978.

*Әд.:* Профессор Ирек Махмутович Рахматуллин // Патология, физиология и эксперим. терапия. 1999. № 3.

**РӘХМӘТУ́ЛЛИН** Ирек Сәмигулла улы (13.12.1937, Свердловск өлкәсенең Вёлс а.), социолог, тарих фән. канд. (1971), тарих фән. д-ры (1987), проф. (1988), ТССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). Казан ун-тын тәмамлый (1966). 1966–88 елларда Казан авиация ин-тында эшли. 1982–2015 тә Казан ун-тында, фәнни коммунизм каф. мөдире (1991–2008 — социол. каф.). Хезмәтләрендә социол. теориясе һәм тарихы, иҗтимагый мөнәсәбәтләр социологиясе, җәмгыятьнең социаль структурасы яктыртыла. Халыклар дуслыгы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: История социалистических учений. К., 1989; История социально-политических учений. К., 1992; Понять общество, в котором мы живём: конструирование национальной государственности. К., 2001 (автордаш); Девиантное поведение как социальная проблема. К., 2004 (автордаш).

**РӘХМӘТУ́ЛЛИН** Исхак Шиһабетдин улы (1897, Казан губ., Зөя өязе Чукры Алан а. — 3.8.1937, Мәскәү), сәясәт эшлеклесе. 1915–17 елларда Казанда мәдрәсәдә укыта. 1917 дә Татар укытучылары берлеге Казан шәһәр һәм губерна оешмасының идарә секретарь-әгъзасы. 1917–1919 ел башында «*Кызыл Байрак*», «*Эшче*» (Казан, Мәскәү) г-талары мөхәррире. 1919 да РКП(б)ның Казан губерна ком-ты каршындагы мөселман бюросының җаваплы секретаре. 1919–20 дә «Башкортстан хәбәрләре» (Әстәрлетамак) г-тасы мөхәррире. 1920 дә дәүләт кризисы вакытында Башкортстан революцион ком-ты рәисе Ә.Ә.*Вәлиди* б-н Башкортстаннан китә. Ә.Ә.Вәлиди, Башкортстанның вәкаләтләрен чикләү б-н ризалашмыйча, большевиклар б-н хезмәттәшлек итүдән баш тарта һәм Урта Азия халыкларының Совет хөкүмәтенә каршы юнәлтелгән милли хәрәкәтенә кушыла. Р. кулга алына һәм аңа карата тикшерү алып барыла (1920–21). Азат ителгәннән соң, Төрки халыкларның үзәк бюросы нәшриятында әдәби хезмәткәр, Татарстан өлкә партия мәктәбендә уку-укыту бүлеге мөдире һәм укытучы. 1922–28 дә Татарстан коммунистлар ун-ты укытучысы һәм уку-укыту бүлеге мөдире (Казан). 1928–31 дә ТАССР мәгариф халык комиссары. 1932–34 тә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тында бүлек мөдире. 1934–35 тә Марксизм-ленинизм ин-тында (Казан): директор, марксизм-ленинизм классиклары хезмәтләрен тәрҗемә итү бюросы җитәкчесе. 1935–36 да Татарстан дәүләт нәшриятында тәрҗемәче. 1936 да кулга алына (к. «*Троцкийчы милләтчеләрнең контрреволюцион-террористик оешмасы*» *эше*). Репрессияләр чоры корбаны; үлгәннән соң аклана (1958).

*Әд.:* Книга памяти жертв политических репрессий. К., 2004. Т. 12.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**РӘХМӘТУ́ЛЛИН** Касыйм Хәлиулла улы (19.9.1920, Кыргызстан АССР, Кустанай ш. — 2.4.2007, Казакъстан Респ-касы, Алма-Ата ш.), философ, филос. фән. д-ры (1968), проф. (1969). Казакъстан ССРның атказ. фән эшлеклесе (1984). Урал пед. ин-тының геогр. ф-тын тәмамлый (1941). 1946–51 дә — комсомолның Актүбә өлкә ком-ты секретаре, бер үк вакытта Укытучыларның белемен камилләштерү ин-ты директоры (Актүбә ш.). 1952–63 тә Югары партия мәктәбенең филос. кафедрасында (Алма-Ата). 1963 тән Алма-Ата халык хуҗалыгы ин-тының философия, 1971 дән Казакъ милли ун-тының филос. һәм методология фәннәре кафедрасында (1990 га кадәр каф. мөдире) эшли. Хезмәтләре табигыятьнең фәлсәфи мәсьәләләрен яктыртуга карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Борьба мировоззрений в космологии. А.-А., 1962; Жизнь во Вселенной. А.-А., 1975; Является ли развитие атрибутом материи // Вопр. философии. 1980. № 8 (автордаш); Принцип единства мира // Принципы диалектики. А.-А. 1984.

**РӘХМӘТУ́ЛЛИН** Салават Ибраһим улы (1.2.1942, БАССРның Ауыргазы р-ны Солтанморат а.), шагыйрь. Татар һәм башкорт телләрендә яза. Әстәрлетамак пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1965), Ауыргазы р-ны мәктәпләрендә укытучы һәм уку-укыту бүлеге мөдире булып эшли. 1982–84 елларда Гафури р-ны Аккүл авылы мәдәният йорты директоры, 1987–92 дә Әстәрлетамак шәһәренең 1 нче интернат-мәктәбендә тәрбияче. «Әйтелмәгән әйтер һүҙҙәрем» (Уфа, 1978), «Күперҙәр» (Уфа, 1985), «Уяну» (Уфа, 1993), «Сулар үргә акса да...» (Уфа, 2001), «Очлы-

тауда» (Уфа, 2004) җыентыклары авторы. Шигырьләре эмоциональ һәм фәлсәфи яңгырашлы, гражданлык мотивлары б-н баетылган. Балалар өчен «Ямгыр, яу, яу!» (Уфа, 1981), «Быйыл мәктәпкә барам!» (Уфа, 1990), «Куян ник кыска койрыклы?» (Уфа, 2001) җыентыклары авторы. Балаларга атап язылган шигырьләре җыйнаклыгы, образлы теле б-н аерылып тора.

*Әд.:* Сафуанов С. Һәр бөртеге энҗе булсын // Тулпар. 1995. № 5.

**РӘХМӘТУ́ЛЛИН** Хаҗи Баязит улы (18.12.1909, Уфа губ., Бәләбәй өязе Яңа Шахово а. — 20.5.1974, Казан), мәдәният эшлеклесе. Казан финанс-икътисад ин-тын (1935), ВКП(б) ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1944) тәмамлый. 1935–36 елларда Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларының Сталин р-н советы башкарма ком-тында бүлек мөдире (Казан). 1936–38 дә ТАССР Финанслар халык комис-тының финанс-бюджет инспекциясе ревизоры. 1938–39 да РСФСР Финанс халык комис-тының ТАССР буенча контроль-ревизия идарәсе контролёры, 1939–40 та СССР ХКС каршындагы Совет контроле комиссиясе уполномоченныеның ТАССР буенча контролёры. 1940–42 дә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты секретаре ярдәмчесе, 1947–51 дә — секретаре. 1944–47 дә ВКП(б) ҮКның Пропаганда һәм агитация идарәсендә (Мәскәү). 1951–56 да ТАССР МС Рәисе урынбасары. 1956–61 дә ТАССР мәдәният министры. 1961–63 тә СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. Р. Татарстанның мәдәни тормышына сизелерлек өлеш кертә. Аның башлангычы б-н Казанда Г.Тукайга һ.б. мәдәният эшлеклеләренә һәйкәлләр куела, Татар опера һәм балет академия театры бинасы төзелеп бетә; Мәскәүдә 1 нче татар сәнгате һәм әдәбияты декадасы уздырыла. 1951–63 тә ТАССР ЮС депутаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*


**РӘХМӘТУ́ЛЛИН** Хафиз Рәхмәтулла улы (1896–1947, Казан), фольклорчы. 1917 елда Тубыл губернасының Тара өязе авылларында «Идегәй», «Атаклы кыз Тукбикә», «Тимер батыр», «Илдан белән Гөлдан» дастаннарының билгесез вариантларын язып ала. 1918–23 тә Тара өязе мәктәпләрендә укыта; бер үк вакытта, 1921–36 да, «Азат Себер» г-тасы мөхәррире урынбасары. 1938 дән Казанда яши, Татарстан китап нәшриятында цензор булып эшли.

*Әд.:* Илдан белән Гөлдан // Әдәби мирас. К., 1992. 2 кит.; Атаклы кыз Тукбикә // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2003. № 3/4; Тимер батыр // Мирас. 2004. № 8.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**РӘХМӘТУ́ЛЛИН** Хәлил Әхмәт улы (23.4.1909, Төркестан, хәзер Кыргызстан Респ-касының Токмак ш. — 10.1.1988, Мәскәү), аэродинамика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1943), Үзбәкстан ССР ФА академигы (1947), Үзбәкстан ССРның, РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1959, 1960), Соц. Хезмәт Герое (1979). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, аэродинамика лаб-ясе мөдире (1937–43). Газ һәм дулкын динамикасы кафедрасын оештыручы һәм аның җитәкчесе (1951–88). Хезмәтләре механиканың динамик проблемаларына: сыгылмалы һәм сыгылмалы-пластик дулкыннар таралу теориясенә, бәрмә дулкыннар дифракциясенә, парашют һәм үткәрүчән җисем аэродинамикалары теориясенә; грунтлар динамикасына, күп компонентлы тирәлекләр хәрәкәтенә, химия технологиясенә карый. Сыгылмалы-пластик тирәлекләр өлкәсендә Р. пластик деформацияләрнең кайтма булмавына бәйле аерым бушану дулкыннарын ача («Рәхмәтуллин дулкыннары»). Аркылы бәрү теориясендә ул сыгылмалы җепләргә бәргәндә хасил була торган дулкын картинасын ачыклый, бу күренеш Бөек Ватан сугышы елларында Мәскәүне саклауда кулланылган һава токарлыгы аэростатларының тросларын исәпләүдә файдаланыла. Грунтлар динамикасы буенча тикшеренү нәтиҗәләре көчле шартлау йөкләнешләре исәпкә алынган гидротехник һәм җир асты корылмаларын исәпләгәндә кулланыла. Р.ның үткәрүчән тирәлек аэродинамикасына караган хезмәтләре парашютларның төрле типларын эшләүдә һәм космик аппаратларны йомшак утыртуда файдаланыла. Р. — күп фазалы тирәлекләрнең үзара үтеп керүле хәрәкәте теориясенә нигез салучы. Ул, беренче булып, берничә кысылучан фаза катнашмасы хәрәкәтенең йомык тигезләмәләр системасын таба, дулкын таралуның төп законнарын анализлый, ике фазалы катнашмадагы чик катлам теориясе нигезләрен билгели; каты һәм сыек кисәкчәләр катнашкан газның тавыш тизлегеннән югары тизлекле ташкыны турындагы мәсьәләне куя һәм чишә. СССР Дәүләт бүләкләре (1949, 1974), Мәскәү ун-тының М.В.Ломоносов исем. (1945), СССР МС (1985, 1990), Үзбәкстан ССРның Бируни исем. Дәүләт (1968) бүләкләре иясе. Дүрт Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Прочность при интенсивных кратковременных нагрузках. М., 1961 (автордаш); Газовая и волновая динамика. М., 1983; Взаимодействие сред и полей. Таш., 1985 (автордаш).



Х.Ә. Рәхмәтуллин.



Ш.С. Рәхмәтуллин.



Ю.У. Рәхмәтуллин.

**РӘХМӘТУ́ЛЛИН** Шамил Сәет улы (7.9.1920, Томск ш. — 1.10.1943, Украина ССРның Чернигов шәһәрендә җирләнә), Сов. Союзы Герое (9.2.1944, үлгәннән соң), гв. капитаны. Бөек Ватан сугышына кадәр гаиләсе б-н Казанга күченеп кайта. 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 дә Мәскәү артиллерия уч-щесен тәмамлый. 1941 дән фронтта, 112 нче Башкорт иреклеләр кавалерия дивизиясенең 275 нче кавалерия полкында артиллерия батареясы командиры (7 нче гв. кавалерия корпусының 14 нче гв. кавалерия дивизиясе). Үзәк фронт гаскәрләре составында Сталинград сугышында (1942–43), Ворошиловград һәм Чернигов-Припять операцияләрендә (1943) катнаша. Днепр елгасын кичеп, шәһәр тибындагы Лоев посёлогы (Белоруссия ССР, Гомель өлкәсе) янында батырлык күрсәтә: 1943 нең 30 сентябрендә, дошман уты астында, үз подразделениеләренең елга аша чыгуын һәм плацдарм өчен сугышын оештыра. Р. полкы, тәүлектән артык дошманның пехота һәм танклар контрһөҗүмен кире кайтарып, кавалерия дивизиясе частьларының елганы кичүен тәэмин итә. Шушы сугышта һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары б-н бүләкләнә. Чернигов шәһәренең бер урамы һәм тыкрыгы, Казанның бер урамы Р. исемен йөртә. Р.ның исеме, 112 нче (16 нчы гв., Чернигов) Башкорт кавалерия дивизиясенең 78 Советлар Союзы Герое исемнәре б-н бергә, БР Милли музее һәм Уфа шәһәре 112 нче (16 нчы гв.) Башкорт кавалерия дивизиясе музеенда мемориаль такта урнаштырыла.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

**РӘХМӘТУ́ЛЛИН** Шиһабетдин Габделгазиз улы (19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башы), тәрҗемәче, нашир. Казан губернасының Ындырчы авылында мулла булып тора. Мөселман Шәрегының «Дүрт дәрвиш хикайәте» (1900), «Әбүгалисина» (1902), «Малик хикайәте» (1906) һ.б. легенда һәм риваятьләрен тәрҗемә итә һәм балалар өчен эшкәртә. Мәдрәсәләр өчен «Татарча-русча перевод» (1893) уку ярдәмлеге авторы. 1890–1900 елларда татар телендә еллык өстәл календаре чыгара.

Әсәр.: Самоучитель татарского языка русским и русского языка татарам. К., 1918.

*Әд.:* Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек. К., 2001.

**РӘХМӘТУ́ЛЛИН** Юныс Усман улы (17.3.1925, Казан — 13.3.1999, шунда ук), радиоинженер, Ленин бүләге лауреаты (1978), СССРның мактаулы радисты (1975), РСФСРның атказ. машина төзүчесе (1983 Ярославль хәрби уч-щесен (1944), Казан авиация ин-тын (1960) тәмамлый. 1951–99 елларда Казан радиоэлектроника фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, баш технолог (1962–69), директорның җитештерү буенча урынбасары (1969–89). Р. җитәкчелегендә илнең 29 пр-тиесендә радио аппаратлары җитештерүнең заманча технологияләре, ш.и. контактлар мәйданчыгы ачык булган күп

катламлы платалар, платаларга дымнан саклаучы тишемләнгән плёнкалар пресслау технологиясе һ.б. эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Ленин бүләге «Пароль» яңа радиолокацион тану системасын эшләгәне өчен бирелә. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**РӘХМӘТУ́ЛЛИНА** Алевтина Петровна (28.1.1958, Удмурт АССРның Игра р-ны Кушья ст.), химик, техник фән. д-ры (2009). 1983 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Бөтенсоюз ясалма каучук фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында эшли. 1988 дән Казан технол. ун-тында, синтетик каучук технологиясе каф. профессоры (2009 дан). Хезмәтләре олеохимик актив өслекле матдәләр нигезендә күп функцияле нәтиҗәле системалар булдыруга карый. Р. эшләгән күп кенә нәтиҗәле композицияләр, карбочылбырлы эластомерлар алу һәм аларны кабат эшкәртү технологияләрендә кулланылып, әлеге синтезның технол. параметрларын яхшырта һәм аларга нигезләнеп ясалган полимер материалларның кулланылыш сыйфатларын күтәрә. Фәнни хезмәтләре «Түбәнкамашин» һәм «Тольяттикаучук» пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 12 авторлык таныклыгы бар. Медаль б-н бүләкләнә.

**РӘХМӘТУ́ЛЛИНА** Вилә Сираҗетдин кызы (18.4.1926, Казан), кино рәссамы. Казан сәнгать уч-щесен (1945), Бөтенсоюз дәүләт кинематография ин-тын (Мәскәү, 1952) тәмамлый. 1952–86 елларда «Ленфильм» киностудиясендә өс киемнәре рәссамы булып эшли. 40 ка якын тулы метражлы кинокартиналар иҗат итүдә катнаша. Арада иң билгеле хезмәтләре: «Алеко» (1953), «Балтыйк күге» (1961), «Кыргый эт Динго» (1962), «Женя, Женечка һәм Катюша» (1967), «Җиденче юлдаш» (1968), «Әни кияүгә чыкты» (1970), «Строговлар» телесериалы (1976) һ.б. 1981 дә «Үзбәкфильм» киностудиясенә өс киемнәре рәссамы итеп чакырыла, 1982 дә «Казакъфильм» киностудиясендә «Хаҗи Мукан» картинасын төшерүдә катнаша. С.-Петербургта яши.

*Әд.:* Гурченко Л.М. Аплодисменты: Повесть. М., 1987.



В.С. Рәхмәтуллина. 1. «Строговлар» кинофильмына сәүдәгәр Евдоким Юткин киеменең эскизы. «Ленфильм». Каләм, тушь, акварель. 1976; 2. Татар хатын-кызлары киеме эскизлары. Каләм, гуашь, тушь. 1980 еллар.



**РӘХМӘТУ́ЛЛИНА** Галимә (19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башы), язучы. Дидактик эчтәлекле «Аналарга яднамә» (1903) шигырьләр, «Иҗмагъ ишеге» (1906) дидактик хикәяләр җыентыклары авторы.

**РӘХМӘТУ́ЛЛИНА** Лина Фазыйл кызы (3.1.1932, Түнтәр р-ны Балтач а.), математик, физика-матем. фән. д-ры (1983), проф. (1985). 1954 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Красавино шәһәрендә (Вологда өлкәсе) мәктәптә укыта, 1955 тән Удмурт пед. ин-тында, 1965 тән Ижевск механика ин-тында, 1966 дан Тамбов химия машиналары ин-тында. 1975 тән Пермь политехник ин-тында (хәзер Пермь техник ун-ты), «Функциональ-дифференциаль тигезләмәләр» фәнни-тикшеренү үзәге җитәкчесе (1994 тән). Р. сызыкча функциональ-дифференциаль тигезләмәләрнең гомуми теориясен төзи; сызыкча кырый мәсьәләләрнең гомуми чишелешен формалаштыра, аларда грин операторының үзлекләрен өйрәнә, кырый мәсьәләләр чишелешенең параметрларга өзлексез бәйлелеге шартларын таба; абстракт функциональ-дифференциаль тигезләмә теориясен эшли (бергәләп).

Хезм.: О канонических формах линейных функционально-дифференциальных уравнений // Дифференциальные уравнения. 1975. Т. 11, № 12; Введение в теорию функционально-дифференциальных уравнений. М., 1991 (автордаш); Элементы современной теории функционально-дифференциальных уравнений: Методы и приложения. М.–Ижевск, 2002 (автордаш); On the integral representation of the Green operator // Functional Differential Equations. 2004. V. 11, № 3–4.

**РӘХМӘТУ́ЛЛИНА** Наилә Кадыйр кызы (23.12.1910, Казан губ. Чистай ш. — 13.12.2002, Мәскәү), җырчы (лирик-колоратуралы сопрано). Урта мәктәптә һәм Казан мед. техникумында укыган вакытта үзешчән сәнгатьтә катнаша. 1930 елдан Татар акад. театрында. 1930 да «Эшче» операсында Сәлимә һәм Сәрби рольләрен башкара. 1931–36 да Үзәк театр сәнгате техникумында (Мәскәү), 1937–41 дә Зур театр студиясендә (А.В.Нежданова классы) укый. 1936–40 та һәм 1944–48 дә Бөтенсоюз концерт берләшмәсе артисты. 1941–44 тә һәм 1950–52 дә Казан филармониясе солисты. Татар композиторлары әсәрләрен, рус халык һәм чит ил классик җырларын башкара. 1930–40 елларда Бөтенсоюз һәм Татар радиоларыннан чыгышлар ясый. Ленинградта 2 нче Бөтенсоюз музыкант-башкаручылар конкурсы лауреаты (1935).

*Әд.:* Зелов Н. В гостях у Наили Рахматуллиной // Советская музыка. 1973. № 8.

**РӘШИДЕТДИ́Н** Фазлуллаһ ибне Әбүл Хәйр әл-Хәмадани (1247, Хәмадан ш. — 18.7.1318, Тәбриз ш.), фарсы галим-энциклопедисты, дәүләт эшлеклесе. Һулагулар дәүләте идарәчесе Абака хан дәверендә күтәрелеп китә (1265–82). 1298–1317 елларда Газан хан, Улҗәйтү, Әбү Сәед илһаннар вәзире. Газан хан идарә иткән дәвердә (1295–1304) Р. булышлыгы б-н адм. һәм икътисади реформалар үткәрелә. Көчле үзәк хакимият тарафдары, төрки-монгол күчмә аксөякләренең аерымлану омтылышларына каршы тора. Улҗәйтү ханны агулауда нахакка гаепләнеп үтерелә. Мед., ботаника, табигыять фәннәре, а.х. һәм төзелеш техникасы, илаһият (сөнниләр) гыйлеме буенча хезмәтләр авторы. «Елъязмалар мәҗмугасы» («Җамигъ әт-тәварих», т. 1–3, М.–Л., 1946–60) хезмәте аңа аеруча танылу китерә. Хезмәтне 1300–01 дән башлап, 1310–11 дә тәмамлый. Р. гарәпләр һәм фарсылар тарихы — кешелек диңгезенә коя торган елгаларның берсе генә, «гомуми тарих» мөселманнарның гына түгел, барлык мәгълүм халыкларның тарихын да үз эченә алырга тиеш; халыклар тарихын чыганакларга нигезләнеп, аларның тарихи традицияләрендә өйрәнергә кирәк, дип исәпли. Хезмәтнең беренче өлешендә — монгол һәм төрки кабиләләрнең, Чыңгыз хан, аның варислары, Иранда Һулагулар дәүләте тарихы, икенче өлешендә мөселман дәүләтләре (монголлар явына кадәр), Һиндстан, Кытай, борынгы яһүдләр, Көнбатыш Европа халыклары һ.б. тарихы бәян ителә. Алтын Урданың 13 йөзнең 2 нче яртысы — 14 йөз башындагы тарихы, аеруча Җүчиләрнең сәяси тарихына һәм шәҗәрәләренә нисбәтле кыйммәтле мәгълүматлар бар. Автор монгол чыганакларыннан, ш.и. Чыңгызыйларның югалган «Алтын дебтер» («Алтын китап») нәсел тарихыннан, ш.у. төрле кулъязмалардан һәм вакыйгаларда катнашучыларның истәлекләреннән файдаланган. 14–17 йөзләрдә татар тарихы белеме дә бу традициядә үсә (мәс., *Кадыйргали бәкнең* «Елъязмалар мәҗмугасы»ның беренче бүлеге Р. китабына нигезләнгән). Р.нең уллары (өлкәләрдә идарә башлыклары) һәм чиновниклар, руханилар б-н хат алышуы Иранның социаль-икътисади тарихыннан кыйммәтле чыганак булып тора.

Хезм.: Переписка. М., 1971.

*Әд.:* Бартольд В.В. Туркестан в эпоху монгольского нашествия // Соч. М., 1963. Т. 1; Фалина А.И. Рашид ад-Дин — врач и естествоиспытатель // Письменные памятники Востока: Ист.-филол. исследования. М., 1974; Арсланова А.А. Остались книги от времён былых. К., 2002.

*А.А.Арсланова, И.Л.Измайлов.*

**РӘШИДИ́** Габделгалләм Габделбадигъ угылы (1848, Чистай өязе, хәзерге Яңа Чишмә р-ны Чертуш а. — 19.11.1923), шагыйрь. Туган авылында, Кормаш авылында, Чистай шәһәрендә белем ала. Соңыннан укыту эшендә. 1890 елдан туган авылында мулла булып тора. 1905 тән иген игә, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1880 нче еллар ахырында шигырь-

ләр яза башлый. Кечкенә күләмле 50 шигырь җыентыклары авторы (1905 елдан соң басыла). Иҗатында хорафатларга ышанучылар б-н көрәш темасын күтәрә («Яңа ишан», 1910; «Җиңел кон итү», 1911), татарларның көндәлек тормышын тасвирлый («Мишәр туе», 1910; «Асрау кыз нәсыйхәте», 1911), фольклор образларга мөрәҗәгать итә («Сак-Сок хәлләре», 1911; «Сөембикә», 1912 һ.б.). Татар халык җырларын җыеп, 9 җыентык бастыра («Хикмәтле җырлар» сериясе 1913 кә кадәр чыга).

*Әд.:* Ф ә т х и А. Татар әдипләре һәм галимнәренең кульъязмалары. К., 1968.

**РӘШИ́Т** (Рәшитов) Әхмәт Әхәт улы (25.3.1936, Буа р-ны Яңа Чәчкап а.), шагыйрь, публицист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1986), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1995). 1957–58 елларда Казакъстан-Себер тимер юлының Семипалат резервында өлкән конструктор булып эшли. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1960), «Бригадир» Апас район г-тасында әдәби хезмәткәр. 1961–96 да (бүленеп) ТАССР МС каршындагы радиотапшырулар һәм телевидение ком-тында (1992 дән «Татарстан» ДТРК): башта Казан телестудиясендә балалар тапшырулары мөхәррире, соңрак, 1968 гә кадәр, Лениногорск шәһәр телевидениесендә өлкән мөхәррир. 1969 дан кабат Казанда: 1974 кә кадәр Татарстан радиосында әдәби-драматик тапшырулар мөхәррире, 1990 нан өлкән мөхәррир. 1974–75 тә «Социалистик Татарстан» г-тасы хәбәрчесе, 1976–88 дә ТАССР Язучылар берлегенең Г.Тукай исем. клубы директоры. Р.нең беренче шигырьләре 1952 дә «Чаян» ж-лында басылып чыга. Аның көчле гражданлык мотивлары б-н аерылып торган «Минем шәҗәрәм» (1970) поэмасы җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә. Буыннар дәвамлылыгы, заманнар бәйләнышы, киләчәккә ышаныч — Р. иҗатында төп темалардан. «Сөембикә» (1987), «Колшәриф» (1990), «Мөхәммәдъяр» (1996), «Без — татарлар» (2003) поэмаларында алар тарихи хәтер җирлегендә тасвирланса, «Авылдашлар» (1972), «Варислар» (1974) поэмаларында шагыйрь игътибарын үз заманының тормыш материалына юнәлтә. «Хатирә» (1972), «Сәяхәтнамә» (1978), «Киек каз юлы» (1982; русчага тәрҗемәсе «Млечный Путь», М., 1983), «Йөрәк кыңгыраулары» (1986), «Давыллар кайтавазы» (1990), «Таң илчесе» (1996), «Фидаиләр»(2003) җыентыкларында Р. дөньяның гүзәллегенә, тормыш-яшәешнең мәңгелегенә дан җырлый. «Кояшлы ил — бәхет иле» (1981) җыентыгы балаларга багышланган. Аның татар халкының милли үзаңы үсешен бәян иткән «Иман яңартканда» (1991) публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре җыентыгы җәмәгатьчелек тарафыннан уңай кабул ителә. Р. шулай ук популяр җыр текстлары авторы да. Казакъ һәм каракалпак классиклары Абай һәм Әҗинияз әсәрләрен, хәзерге заман шагыйрьләре Б.Исхаков, М.Әлимбаев, Р.Әхмәтова, Н.Бобоглу, Ж.Аймурзаев һ.б. шигырьләрен татар теленә тәрҗемә итә. Р.нең әсәрләре рус, украин, белорус, латыш, казакъ, чуаш телләренә тәрҗемә ителә. ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләге лауреаты (1993).

Ә с ә р.: Ике гасыр арасында. К., 2002.

*Әд.:* Г а л и у л л и н Т. Тарих мизгелләре // Казан утлары. 1997. № 8; Ф ә й з у л л и н Р. Яшәүгә ышаныч // Сайланма әсәрләр. К., 1998. Т. 4; М а н с у р о в З. «Мөмкин» белән «түгел» арасы // Казан утлары. 2006. № 3.

*Г.М.Габделхакова.*

**РӘШИ́ТОВ** Фрид Гайни улы (12.1.1937, Куйбышев өлкәсенең Иске Кулаткы р-ны Яңа Мостяк а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1995), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2002), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2003). ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы (2008), Пенза өлкәсенең Сосновоборск посёлогында пед. уч-щесен (1955), Саратов ун-тын (1960) тәмамлый. 1965 елдан Саратов ун-тында укыта. 1985 тән Россия сәүдә-икътисад ун-тының Саратов ин-тында (ф-лында): иҗтимагый фәннәр, политология, социаль-гуманитар фәннәр (1985–2007) кафедралары мөдире. Хезмәтләре 20 йөз башында Россиядә рев-цияләр тарихына, татар халкы тарихына багышлана. 1989 дан — Саратовта «Идел» татар мәдәни-агарту берләшмәсе, 1997–99 да Саратов өлкәсенең татар милли-мәдәни автономиясе рәисе. Бөтендөнья татар конгрессларында (Казан, 1997, 2002, 2007, 2012), 1 нче Бөтендөнья татар галимнәре форумында (Казан, 2007) катнаша.

Х е з м.: Альтернатива Октября: мирный или насильственный переворот. Саратов, 1990; Татары: История в документах. Саратов, 1998; История татарского народа с древнейших времён до наших дней. Саратов, 2001; О прошлом и настоящем татарского народа. Саратов, 2003; Революция 1917 года: Борьба партий, выбор народа. Саратов, 2006.

**РЕАЛИ́ЗМ**, 19 йөздән башлап әдәбият һәм сәнгатьтә чынбарлыкның, иҗтимагый тормышның һәм шәхеснең асылын кабат торгызу чарасы буларак кабул ителгән сәнгати-әдәби ысул, иҗат тибы. Чынбарлыкны объектив чагылдыру, типик характерларны, конфликтларны, вакыйгаларны үзләренә охшатып тасвирлау, сурәтләнгәннәрне автор күңеленнән уздырып, иҗтимагый-тарихи вакыйгалар тәэсирендәге күренешләр итеп карау (социаль детерминизм) — реалистик сәнгатькә хас үзенчәлекләр. Гомумэстетик атама буларак Р. 18–19 йөзләрдә барлыкка килә. Бүгенге мәгънәдә «Р.» термины Россиядә — беренче тапкыр әдәби тәнкыйтьче П.В.Анненков, Франциядә Ж.Юссон тарафыннан кулланыла; рус әдәбият белемендә ул Н.А.Добролюбов, Д.И.Писарев, Ф.М.Достоевский һ.б.ның тәнкыйть мәкаләләре аша урнаша. Татар әдәбият белеменә бу атама 1910 елдан соң килеп керә; теоретик планда эшкәртелеп, Г.Ибраһимов, Ж.Вәлиди хезмәтләрендә файдаланыла.

18 йөз ахырында — 19 йөз башында татар иҗтимагый фикеренә мәгърифәтчелек идеяләре үтеп керә һәм Г.Курсави, Г.Утыз Имәни, бигрәк тә Г.Кандалый әсәрләрендә (руханиларны тәнкыйтьләү, белемгә, тәрәккыяткә чакыру, югары әхлакый идеалларны яклау) чагылыш таба. 19 йөзнең 2 нче яртысында туган татар мәгърифәтчелек хәрәкәте Россия һәм Европа мәгърифәтчелегенең аерылгысыз өлешенә әверелә. Мәгърифәтчелек б-н бәйле яңа идея-эстетик эзләнүләр татар поэзиясендә аеруча көчле чагыла. Г.Чокрый, Акмулла, Я.Емельянов әсәрләрендә җәмгыятьтәге тәртипләр тәнкыйтьләнә, гаделлек, тигезлек, кешелеклелек принципларына һәм мәгърифәтле кеше образына басым ясала. Хатын-кызның җәмгыятьтә тоткан урынын билгеләү татар мәгърифәтчелек Р.ының мөһим темасына әверелә. Татар драматургиясенә нигез салучылар Г.Ильяси һәм Ф.Халиди пьесаларында да (вакыйгаларның асылын «мәгърифәтлеләр» һәм искегә ябышып ятучылар арасындагы гаилә-көнкүреш конфликты тәшкил итә) хатын-кыз мәсьәләсе үзәккә куела. Татар прозасында мәгърифәтчелек Р.ына нигез салган К.Насыйри, М.Акъегетзадә, З.Бигиев тирәлекне бәяләүдәге бердәнбер кыйммәт итеп акыл көчен күрсәтәләр. М.Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» романының төп герое кешедә актив тормыш позициясен югары бәяли, сәләт һәм белем изге максатта, милләтеңә хезмәт итү өчен файдаланылырга тиеш, дип саный. Романда татар җәмгыятенең социаль-икътисади яктан артта калуы мәсьәләсе куела, милләт язмышы мотивы пәйда була. Мәгърифәтчеләр тәҗрибәсе 20 йөз башында драматургиядә — Г.Исхакый, Г.Камалларның беренче пьесаларында, поэзиядә — М.Гафури шигырьләре һәм поэмаларында, Г.Тукайның тәүге шигырьләрендә, прозада — Р.Фәхретдинов, Ф.Кәрими, Г.Исхакый, Г.Чыгътай, З.Һади, Ш.Мөхәммәдов һ.б. (мәс., Р.Фәхретдинов, Ф.Кәрими әсәрләрендә беренче планга укымышлы, тәрбияле кеше идеалы чыга) әсәрләрендә үстерелә һәм баетыла. Язучылар әдәбият кешене гражданлык әхлагы рухында тәрбияләргә, бозыклыкка бирешмәскә өйрәтергә тиеш дип саныйлар. Ә бу, үз чиратында, әсәрләрдә публицистик, үгет-нәсыйхәт пафосы көчәюгә китерә; яңалыкның искелек (җәдитчелекнең кадимчелек) б-н көрәшү мотивлары активлаша; яңалык авыр көрәштә явызлыкны җиңеп чыга. Р.Фәхретдинов повестьларында тәнкыйть искечә укыту ысулына һәм кадимче муллаларга каршы юнәлтелә (к. *Кадимчелек*). З.Һади, Ш.Мөхәммәдов иҗатларында иҗтимагый тәнкыйть элементлары көчәя төшә: язучылар татар сәүдәгәрләренең, мәдрәсә хуҗаларының, муллаларның наданлыгын һәм әхлаксызлыгын фаш итәләр. Г.Исхакыйның «Тәгаллемдә — сәгадәт» дидактик хикәясендә аталар буынының наданлыгы тәнкыйтьләнә, мәгърифәтле аналар образы идеаллаштырыла; «Кәләпүшче кыз», «Бай угълы» әсәрләрендә татар җәмгыятендәге әхлаксызлыкка тискәре мөнәсәбәт чагыла.

20 йөз башында татар әдәбиятында формалаша барган тәнкыйди Р.ның төп бурычы татар халкын гасырлар буе дәвам иткән «йокыдан» уятудан гыйбарәт була. Бу агымның асылын яшәп килүче вазгыятьне тәнкыйтьләү, кешенең камил түгеллеге хакында уйланулар, искечә яшәү формасын яңасына алмаштыру кирәклеген раслау, татар халкы язмышы өчен борчылу тәшкил итә. Милли тор-

мыштагы, җәмгыятьтәге аерым катламнар көнкүрешендәге теге яки бу күренешләрдән көлү аша авторлар укучыга үзләренең идеалларын җиткерергә омтылалар (Г.Камалның «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре», «Бүләк өчен», И.Богдановның «Помада мәсьәләсе» комедияләре, Ф.Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» повесте, «Яшьләр», «Тигезсезләр» драмалары, «Сәмигулла абзый» хикәясе, Г.Исхакыйның «Кыямәт», «Җәмгыять» пьесалары һ.б.). Җәмгыятьтәге иҗтимагый-әхлакый җитешсезлекләрне гаепләү, көлкегә калдыру сәнгати идеянең бер өлешенә әйләнә. Тәнкыйди Р. татар әдәбиятында берьяклылыгы, автор позициясенең ачыктан-ачык белдерелүе б-н аерылып тора. Г.Исхакыйның «Мөгаллим» драмасында, С.Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!», Г.Камалның «Беренче театр» комедияләрендә һ.б.ларда авторлар геройларга карата тискәре мөнәсәбәтләрен белдереп кенә калмый, искечә яшәүне гыйбрәт итеп, ялгыш юл буларак бәяли дә. Тәнкыйди Р. татар әдәбиятына яңа геройлар бирә, аерым катламнар көнкүрешен тасвирлаудан башлап, милләт язмышын чагылдыруга кадәр юл уза.

1920–30 еллар соц. Р. формалашкан чор була. Ул марксизм-ленинизм классиклары моделе буенча, көрәш аша һәм көч кулланып тарихны тудыруда катнашучы актив шәхесне тәкъдим итә. Рәсми эстетика ноктасыннан караганда, бу сәнгать пролетариат һәм соц. җәмгыять мәнфәгатьләрен чагылдыра. Р. тарихилыкның зарурлыгын, шәхси бәхет — «кешелекнең бәхетле киләчәгенә» фидакарь хезмәт итү, ә тарихи оптимизмның чыганагы — кешене «гадел җәмгыять» төзүгә тарту, дигән фикерне раслый.

Аерым бер социаль заказ үти торган, сәяси тенденциозлыкка ия әсәр тудыру ысулы буларак соц. Р. татар әдәбиятында 1917–32 дә барлыкка килә. Ш.Усманов, М.Гафури, Ф.Сәйфи-Казанлы һ.б. язучылар әсәрләрендә кешенең яшәү мәгънәсе үз-үзен корбан итүгә кайтып кала торган яңа җәмгыять төзелү тасвирлана. Татар соц. Р. әдәбияты оптимизм һәм коммунистик идеяләрнең җиңүенә ышаныч пафосы б-н сугарыла. 1930 елларда соц. Р. әдәбиятта бердәнбер рөхсәт ителгән эстетик концепция буларак ныгытыла (М.Әмирнең «Агыйдел» повесте, «Саф күңел» романы, «Миңлекамал» драмасы; Г.Бәшировның «Сиваш» повесте, «Намус» романы; И.Газинең «Онытылмас еллар» трилогиясе; К.Нәҗминең «Язгы җилләр» повесте; Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы; Ш.Камалның «Матур туганда» романы; К.Тинчуринның «Җилкәнсезләр» драмасы), сәяси мәсьәләләрне хәл итү әхлакый нормаларны үтәүдән өстен куела. Бер үк вакытта, 1941–56 да, татар әдәбиятында гуманистик башлангычның көчәюе күзәтелә: беренче планга халык мәнфәгатьләре чыга, гомумкешелек кыйммәтләре рәтенә ватан, туган як төшенчәләрен кертә башлыйлар. 1960 еллардан башлап шәхеснең үзкыйммәте турында караш туа, җәмгыять һәм шәхесне үзгәртүче көч буларак хезмәтне пропагандалау көчәя (Г.Ахуновның «Чикләвек төше» повесте, «Хәзинә» романы), милли яшәешнең күпгасырлык мәдәни, психол., этнографик, көнкүреш һәм әхлакый традицияләре б-н кешенең бәйләнеше ассызыклана. Бу чорда агым нигезенә «кешелеккә йөз белән борылган» социализм идеясе салына. 1980–90 елларда, дәүләт мәнфәгатьләренең шәхси мәнфәгатьләрдән өстенлеге турындагы караш сакланса да, кеше язмышы, кеше бәхете өчен җәмгыятьнең җаваплылыгы темасы барлыкка килә. Бу хәл соц. Р.ның үз-үзен инкяр итүенә китерә.

«Авыл проза»сы чикләрендә язылган әсәрләрдә крәстиян (авыл) Р.ы агымы тәкъдим ителә. Аның үзәк темасы — авыл, төп герое — җир хуҗасы булудан читләштерелгән крәстиян. 1970 еллар СССР халыклары әдәбиятында заманча проблема һәм ситуацияләр күмәкләшү авырлыгын кичергән крәстияннар язмышына бәйләп яктыртыла. Халык яшәешенең авылда сакланып калган рухи терәкләре илне яңарту нигезләре итеп күрсәтелә башлый. Крәстиян Р.ының кайбер концептуаль кагыйдәләре рәсми совет идеологиясенә кискен каршы килә. Эшчеләр сыйныфын идеаллаштыру урынына, тарихи һәм эстетик идеал буларак, авыл кешесен югары күтәрү, интернационализм идеяләре урынына милли идея (А.И.Солженицын, В.И.Белов, В.П.Астафьев, В.М.Шукшин, В.Г.Распутин әсәрләре) тәкъдим итү шундыйлардан. Татар әдәбиятында мөстәкыйль агым буларак крәстиян Р.ы 1960 елларда барлыкка килә. Аның кысаларында язылган әсәрләр элегик мотивлар б-н сугарыла, татар авылының милли үзенчәлеген югалтуы сентиментальлек һәм өметсезлекнең сәбәбенә әверелә. Үткән һәм бүгенге көн киләчәккә каршы куела (А.Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар», «Берәү», Р.Төхвәтуллинның «Йолдызым», «Авылдашым Нәби», М.Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» повестьлары; С.Рәфыйковның «Авыл иртәсе» романы). 1970 елларда әхлакый мәсьәләләргә игътибар көчәя, автор позициясе тәнкыйди юнәлеш ала (А.Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән», «Әтәч менгән читәнгә» повестьлары; М.Мәһдиевнең «Каз канатлары» романы, «Исәнме, Кәшфи абзый!» повесте; Ә.Баянның «Тау ягы повесте» һ.б.). Шулай итеп, әдәби әйләнешкә яңа характерлар кертелә, традицион әхлакый кыйммәтләр кабат тергезелә, халыкның милли яшәешенә, традицияләренә, гореф-гадәтенә аерым игътибар бирелә башлый.

Магик Р. үзендә бүгенге көнне һәм тарихны, гадәти күренешләрне һәм гадәттән тыш хәлләрне берләштерә. Анда фантастика һәм чынбарлык арасындагы аерма югала, хыялый күренешләр гадәти чынбарлык кануннары буенча үстерелә. Р.ның бу төрен файдалану кешеләргә берләшү кирәклеге турындагы фикерне расларга, яшәп килгән канун һәм нормаларны тәнкыйтьләргә, яхшылыкка ышанычны тергезергә мөмкинлек бирә. Татар әдәбиятында магик Р. мөстәкыйль агым буларак формалашмый, ләкин аның аерым чалымнары Н.Гыйматдинова әсәрләрендә («Сихерче», «Ут күбәләге», «Кыргый», «Китәм, димә») күзәтелә. Аларда реаль тормыштан «читтә калган» геройлар ике дөнья чигендә сурәтләнәләр.

20 йөзнең 2 нче яртысы дөнья әдәбиятында барлыкка килгән психол. Р., интеллектуаль Р., неореализм кебек агымнар игътибарны кешенең эчке дөньясына юнәлтә. Ф.Бәйрәмованың психол. прозага караган «Болын», «Битлек», «Кем?», «Су кызы» повестьларында төрле сәнгати чаралар ярдәмендә кешенең тышкы шартлар тәэсирендә үзгәрми кала торган аң төпкеле, тирән психологиясе ачыла. Бу күренеш совет әдәбияты кысаларында формалашкан детерминизм традициясе җирлегендә сәнгати яңалык булып кабул ителә.

Бүгенге татар прозасында Р. үсеше социаль-тарихи контекст б-н билгеләнә: авторлар әсәрләрендә бүгенге көнне тасвирларга, заманга хас проблемаларны чагылдырырга омтылалар. Тәнкыйди Р. традицияләрен дәвам итеп, алар кеше һәм иҗтимагый тирәлек мөнәсәбәтләренә (Ф.Садриевның «Таң җиле» романы, «Бәхетсезләр бәхете» трилогиясе), реаль тарихи вакыйгаларга (Ф.Бәйрәмованың «Караболак» романы) мөрәҗәгать итәләр. Тәнкыйди тасвирлау объекты итеп бүгенге көн генә түгел, тарихи үткәннәр дә күрсәтелергә мөмкин (Ф.Сафинның «Саташып аткан таң» романы). Бүгенге татар әдәбиятында тәнкыйди юнәлеш төрле жанр һәм стиль вариантларында тәкъдим ителә. Әйтик, Т.Галиуллин «Сәет Сакманов» трилогиясенә кергән романнарын детектив формада яза.

Реалистик тасвирлау кысаларында бүгенге татар әдипләре еш кына социаль, милли һәм фәлсәфи мәсьәләләрне берләштерергә омтылалар.

20–21 йөзләр чигендә дөнья сәнгатендә һәм татар әдәбиятында яңа агымнар барлыкка килү эстетик чаралар куллану мөмкинлеген киңәйтә, текстның күпмәгънәлелеге көчәя, әсәр семантикасының колачы киңәя.

*Әд.:* Х а л и т  Г.  Яңа гасыр поэзиясе: XX йөз башы (1905–1917 еллар) татар поэзиясендә иҗат методы, лирик герой, традиция һәм новаторлык мәсьәләләре. К., 1979; С в е р и г и н  Р.  Яңа геройлар һәм яңа алымнар. К., 1985; Г а н и е в а  Р.К.  Совет көнчыгыш әдәбиятларында иҗат методы мәсьәләләре. К., 1988; Г а й н у л л и н  М.  Татарская литература и публицистика начала XX века. К., 1966; Н и к о л а е в  П.А.  Реализм как творческий метод: Ист.-теорет. очерки. М., 1975.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**РЕА́ЛЬ УЧИ́ЛИЩЕЛӘР**, ир балалар өчен гомуми урта белем бирү уку йорты. Гадәти классик (гимназия) системадан аермалы буларак, 19 йөзнең 1 нче яртысында Европа илләрендә эшләнгән «реаль белем бирү» системасына туры китереп оештырылалар. Россиядә 1864 елдан реаль гимназияләр ачыла, алар 1872 дә Р.у. итеп үзгәртеләләр, урта белемле техник белгечләр, техник һәм махсус югары уку йортлары өчен абитуриентлар әзерлиләр. Аларның программаларында матем., механика, физика, технол., сызым, рәсем фәннәренә зур игътибар бирелә. Борынгы телләр өйрәнелми, француз һәм немец телләре аз күләмдә өйрәнелә. 1888 гә кадәр Р.у.дә уку срогы 6 ел була, тәмамлаучыларның ба-

ры тик техник һәм махсус уку йортларына гына укырга керү хокукы була. 1888 дән 7 нче класслар ачыла, аны тәмамлаганнан соң, укучылар университетларның мед. һәм физика-матем. ф-тларына укырга керә ала. Барлык Р.у., дәүләт уку йорты буларак, Халык мәгарифе министрлыгы карамагында була, шул ук вакытта өлешчә шәһәр үзидарә органнары тарафыннан да финанслана. Р.у. Казанда (1875, 1907), Алабуга (1878), Бөгелмә (1903), Минзәләдә (1914) эшли. 1918 дә бердәм уку йортлары итеп үзгәртеләләр. Ш.у.к. *Казандагы беренче реаль училище*.

**РЕБИ́НДЕР** Пётр Александрович (21.9.1898, С.-Петербург — 12.7.1972, Мәскәү), физик-химик, химия фән. д-ры (1929), СССР ФА акад. (1946; 1933 тән мөхбир әгъза), Соц. Хезмәт Герое (1968). 1924 елда Мәскәү ун-тын тәмамлый. СССР ФАнең Физика һәм биофизика ин-тында эшли (1922–32), бер үк вакытта, 1923–41 дә, Мәскәү пед. ин-тында, проф. (1929). 1935 тән СССР ФАнең Физик химия ин-тында дисперс системалар бүлеге мөдире, 1942 дән Мәскәү ун-тының коллоид химия каф. мөдире. СССР ФАнең Физик-химик механика һәм коллоид химия проблемалары буенча фәнни советы рәисе (1958 дән). Хезмәтләре дисперс системаларның һәм өслекчә күренешләрнең физик химиясенә карый. Р. каты өслекләрнең чылануы б-н аларның адсорбцион катламнарының характеры һәм туену дәрәҗәсе арасындагы бәйләнешне ачыклый, бу ачыш файдалы казылмаларны флотацион баету теориясен үстерүдә мөһим роль уйный. Күбекләр һәм эмульсияләр хасил итү һәм аларны тотрыклыландыруның, эмульсияләрдә фазалар алмашу барышының төп закончалыкларын ача. Актив өслекле матдәләрнең судагы эремәләре үзенчәлекләрен тикшерә, юу тәэсиренә коллоидлы-химик процессларның катлаулы комплексы да катнашуын билгели. Дисперс системаларның реологик үзлекләрен характерлау өчен оптималь параметрлар сайлап ала һәм дәлилли, аларны билгеләү алымнарын тәкъдим итә. Минераль беркеткечләрнең гидратацион кату механизмын ачыклый. Адсорбцион актив тирәлек тәэсирендә каты җисемнәрнең (аерым алганда, металларның) механик ныклыгы кимү күренешен ача («Ребиндер эффекты»), шуның б-н бик каты һәм авыр эшкәртелүчән материаллар эшкәртүне җиңеләйтү юлларын эшли. Фәннең яңа өлкәсен — физик-химик механиканы булдыра. Р.ның тикшеренү нәтиҗәләре күп кенә технол. процессларны (каты токымнарда бораулау, каты материалны ваклау, металларны басым астында һәм кисеп эшкәртү) интенсивлаштыру һәм яхшырту максатында файдаланыла. Бөек Ватан сугышы елларында СССР ФА Физик химия ин-тының Казанга эвакуациясе вакытында (1941–44) оборона максатындагы эшләрне оештыра һәм җитәкли. Актив өслекле матдәләр буенча халыкара ком-тының СССР Милли ком-ты рәисе (1967 дән), «Коллоидный журнал»ның баш мөхәррире (1968 дән). СССР Дәүләт бүләге (1942), СССР ФАнең А.Н.Бах исем. бүләге лауреаты. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.


П.А. Ребиндер.

Хезм.: Физико-химия флотационных процессов. М.–Л., 1933 (автордаш); Физико-химия моющего действия. Л.–М., 1935 (автордаш); Понизители твёрдости в бурении. М.–Л., 1944 (автордаш).

*Әд.:* Пётр Александрович Ребиндер / Материалы к биобиблиогр. учёных СССР. Сер. хим. наук. М., 1971. Вып. 45; Волков В.А., Вонский Е.В., Кузнецова Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991; Академик Пётр Александрович Ребиндер (к 100-летию со дня рождения). М., 1998. *В.Г.Абзалова.*

**РЕБРО́ВСКАЯ** Валентина Александровна (25.2.1943, Лаеш р-ны Яңа Поляна а.), спортчы (велосипед спорты — шосседа узышу), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1973). Смоленск физкультура ин-тын тәмамлый (1970). Воровский исем. СКда тәрбияләнә (Казан, тренеры Н.Фәйзуллин). СССР чемпионы (1967–75, СССР җыелма командасы составында шәхси һәм команда зачётларында), Бөтенсоюз күпкөнле велосипедта узышуда җиңүче (1970–71, 1973–74), дөнья чемпионатында көмеш медаль алучы (1974). 1961–68 дә Казан штепсельле аергычлар з-дында эшли. 1975–2003 тә Профсоюзларның Татарстан респ-ка советы комплекслы Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тренер-укытучы. Медаль б-н бүләкләнә.

**«РЕВИЗО́Р»**, Н.В.Гогольнең 5 күренештән торган комедиясе. 1836 елда языла (соңгы редакциясе — 1842). Рус драма репертуарына нигез салучы пьесаларның берсе. Казанда беренче тапкыр 1836 ның сентябрендә гастрольгә килгән М.С.*Щепкин* тарафыннан сәхнәләштерелә. 1869 да пьеса буенча спектакль тәүге тапкыр цензура бозуына дучар ителми генә П.М.*Медведев* тарафыннан куела. 1886 да пьесаның язылуына 50 ел тулу уңаеннан спектакль Панаев бакчасындагы җәйге театр сәхнәсендә «Ревизор» чишелеше» б-н бергә бара. Беренче актёр (М.С.Щепкин) ролен Медведев башкара. 19 йөз дәвамында Казан шәһәр театры сәхнәсендә «Р». ел саен куела. Алдагы елларда спектакль Мәскәү художество театры актёры А.И.Канин тарафыннан 1901, 1902, 1908 дә — Н.И.Собольщиков-Самарин антрепризасында, 1910 да — Н.Д.Кручинин антрепризасында, 1912 дә В.В.Образцов антрепризасында күрсәтелә. 1913, 1915–17 һәм 1919 да спектакль бер үк вакытта Казан шәһәр театры һәм Яңа клуб сәхнәләрендә бара; сәхнәгә куючы режиссёрлары — П.Н.Добровольский, А.П.Двинский, М.Ф.Добряков, А.И.Каширин. Совет Зур театры (хәзер — Казан Зур драма театры) сәхнәсендә «Р.» 1922 дә — реж. В.С.Зотов, 1925 тә — Л.Ф.Лазарев, 1933 тә — В.А.Чиркин, 1939 да — Г.П.Ардаров, 1944 тә — Е.Г.Гаккель, 1994 тә А.Я.Славутский тарафыннан куела. Казан театры сәхнәсендә Городничий ролен М.С.Щепкин, П.М.Медведев, Ф.В.Григорьев, А.В.*Калаганов*, Г.Н.*Прытков*, Хлестаков ролен А.П.*Ленский*, Ю.М.Юрьев, А.Д.Гусев, Н.И.Якушенко башкара.

Татар театры сәхнәсендә спектакль беренче тапкыр 1916 да «Сәйяр» труппасы җитәкчесе Г.*Кариев* тарафыннан куела. Спектакльдәге рольләрне башкаручылар: Городничий — Г.Кариев, Хлестаков — К.Тинчурин, Осип — Камал I, Анна Андреевна — Г.Болгарская, Марья Антоновна — Н.Таҗдарова, Земляника — Х.*Колмәмәт*, Ляпкин-Тяпкин — Н.Сакаев, Бобчинский — Камал II, Добчинский — Б.Болгарский. 1920 дә «Р.» М.*Мутин* тарафыннан куела; рольләрдә — М.Мутин (Городничий), С.Айдаров (Хлестаков), Н.Сакаев (Осип), К.Шамил (Бобчинский), М.Вәлишин (Добчинский). 1926 да Татар акад. театрында «Р.» спектакле Г.Девишев куюында бара; 1928 дә К.Тинчурин тарафыннан куела; спектакльнең премьерасы Казан Зур драма театры сәхнәсендә 9 мартта күрсәтелә, пьесаның тәрҗемәсе З.Солтанов тарафыннан кабат эшләнә; Городничий ролен — З.Солтанов, Хлестаковны К.Тинчурин уйный. 1929 һәм 1933 тә спектакль яңадан сәхнәгә кайтарыла. 1949 да Ш.*Сарымсаков* тарафыннан куела. Составында: Городничий — Н.*Гайнуллин*, Хлестаков — Г.*Шамуков*, Осип — Г.*Надрюков*, Анна Андреевна — Ф.Камалова, Марья Антоновна — М.Шәрипова, Ляпкин-Тяпкин — М.Уразиков, Хлопов — Ф.Халитов. «Р.» Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) сәхнәсендә дә (1936 да — реж. А.Ю.Вилинский, 1958 дә — реж. Л.Г.Щеглов; Городничий ролен П.А.*Мулярчик* башкара) куела.





Н.В. Гоголь пьесасы буенча куелган «Ревизор» спектакленнән күренешләр: 1. Г. Камал исем. Татар акад. театрында. 1949. (Пошлёпкина – Л. Салигаскәрова; Осип – М. Надрюков; Хлестаков – Г. Шамуков); 2. В.И. Качалов исем. Казан Зур драма театрында. 1994.

*Әд.:* К р у т и И. Русский театр в Казани. М., 1958; И л я л о в а И. Театр имени Камала. К., 1986; И л я л о в а И., И н г в а р И. Русский театр в Казани. К., 1991; Б л а г о в Ю. «... получил прозвище Казанский». К., 2001.

*Ю.А.Благов, И.И.Илялова.*

**РЕВО́** Михаил Васильевич (19.9.1889, Чернигов губ. Кролевец ш. — 1962, Украина ССРның Харьков ш.), микробиолог, вирусолог, мед. фән. д-ры (1936), вет. фән. д-ры (1939), проф. (1939), Украина а.х. фәннәре академиясе хакыйкый әгъзасы (1959), Украина ССРның атказ. фән эшлеклесе (1948). Варшава вет. ин-тын (1912), Харьков ун-тының мед. ф-тын (1918) тәмамлагач, вет. табибе булып эшли. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1925–36 елларда Киев вет.-зоотехния ин-тында, микробиол. каф. профессоры. 1937–43 тә Казан вет. ин-тының микробиол. каф. мөдире. 1943–62 дә Харьков вет. ин-тының микробиол. һәм ветсанэкспертиза каф. мөдире, бер үк вакытта Украина игенчелек ин-тының микробиол., вирусология һәм иммунология бүлеге мөдире. Хезмәтләре а.х. терлекләрендә тилчә, түләмә авыруларын өйрәнүгә, бруцеллёз авыруына вакытында диагноз куюга карый.

Х е з м.: Реакция изогемагглютинации у однояйцевых и двуяйцевых близнецов // Ветеринарное дело. 1928. № 6; Дальнейшее изучение ящурного вируса // Ветеринарное дело. 1928. № 8.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**РЕВОЛЮЦИО́Н ШТАБ**, Казан Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Советының гадәттән тыш органы. Казан Советы тарафыннан 1918 елның февралендә, оештырылуы турында 1918 нең 1 мартында Бөтенроссия мөселман гаскәриләре корылтаенда игълан ителәчәк *Идел-Урал Штаты* төзү планының тормышка ашырылуына каршы тору максатыннан булдырыла. Штабның рәисе — К.Я.Грасис, сәркәтибе — С.С.Сәетгалиев, әгъзалары — С.М.Брауде, С.Гаинцев, А.Г.Гинцбург, Н.Д.Ефремов, А.И.Карпов, В.И.Мохов, В.Н.Скачков, М.Х.Солтангалиев, Я.С.Шейнкман, К.Шнуровский, К.Л.Якубов һ.б. Р.ш. Казан губернасында хәрби хәл игълан итә һәм «шәһәрдә һәм губернадагы тәртипне бозуга юнәлдерелгән һәртөрле чыгышларны һичнинди кисәтүләрсез туктатачагы» турында кисәтә. 27 февральдә Р.ш.ның революцион тәртипне саклау эшендәге вәкаләтләре һәм бу уңайдан күрелгән чараларның сәбәпләре турындагы 1 нче боерык басылып чыга. 2 нче боерык б-н шәһәр һәм губернаның барлык газеталары, боерык үтәлмәгән очракта, ябылу алдына куелып, Р.ш. һәм Казан Советының бөтен карарларын беренче битләрендә бастырырга мәҗбүр ителә. Казан Советы каршындагы Мөселман халык комис-тына Р.ш. исеменнән: «1) Шәһәр татарларының авылныкылар белән берләшүен булдырмас өчен, барлык көч һәм энергияне куярга; 2) Бистәнең татарлар яшәгән өлешендә контрразведка оештырырга; 3) Татар бистәсендәге туплар һәм корал исәбен ачыкларга» яшерен күрсәтмә бирелә. 28 февральдә, Идел-Урал Штаты төзелү алдыннан, Р.ш. боерыгы б-н Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең икенче корылтае җитәкчеләре Җ. һәм И.Алкиннар, Й.Мозаффаров, Г.Токымбәтов кулга алына. Җавап йөзеннән корылтай делегатлары Мөселман революцион штабы төзиләр һәм кулга алынганнарны кичекмәстән иреккә чыгару таләбе куелган карар кабул итәләр. Казанда кораллы бәрелеш куркынычы туа. Р.ш. һәм Мөселман революцион штабы арасында барган сөйләшүләр кулга алынганнарны азат итү шартлары билгеләнгән килешү төзүгә китерә: 1) барлык мөселман оешмалары, милли мәсьәләне хәл итүдә вәкаләтле орган — Казан губернасының Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Советының Учредительләр җыены чакырылганга кадәр, Идел-Урал Штатын төзү буенча эш алып бармаска тиеш; 2) Казан губернасында хакимиятне, бөтен тулылыгы б-н, фәкать Казан Советы һәм Мөселман халык комис-ты тәшкил итә; 3) барлык мөселман хәрби көчләре Мөселман халык комис-ты карамагына тапшырыла; 4) кулга алынганнар азат ителә һәм Мөселман социалистлар ком-ты җаваплылыгына тапшырыла. Җитәкчеләре иреккә чыгарылганнан соң, корылтай үз эшен Казанның Болак аръягында дәвам итә. 3 мартта Р.ш. завод эшчеләреннән сугышчан отрядлар оештыру турында карар чыгара. 1918 нең 28 мартында, ХКС каршындагы Эчке Россия мөселманнары эшләре комис-ты карары б-н, «*Болак арты республикасы*» исеме бирелгән милли-демократик хәрәкәт үзеген юк итү башлана, шуннан соң штаб үз эшен тәмамлый.


*Әд.:* Первый год пролетарской диктатуры в Татарии. К., 1933; Х а й р у т д и н о в Р.Г. Трудное возрождение (февраль 1917–1920 гг.). К., 1992.

*Р.Х.Әхмәтҗанов.*

**РЕВОЛЮ́ЦИЯ КӨРӘШЧЕЛӘРЕНӘ́ ХАЛЫКАРА́ ЯРДӘ́М ОЕШМАСЫ́** (МОПР), 1922–47 елларда капиталистик илләрдәге сәяси тоткыннарга, фашизмга каршы көрәшүчеләргә ярдәм күрсәтә. МОПРны нигезләүче һәм аңа җитәкчелек итүчеләрнең берсе — Ю.З.Мархлевский. 1927 елда оешма 8 млн. кешене эченә алган 44 милли секцияне берләштерә. МОПРның СССР секциясе — арада иң зурысы (1937 дә — 9 млн. га якын кеше). 1923 тән башлап, ел саен 18 мартта барлык илләрдә Халыкара МОПР көне уздырыла. Оешма б-н Мәскәүдә урнашкан һәм МОПРның бөтендөнья конгрессларында сайлап куела торган Башкарма ком-т җитәкчелек итә. МОПРның Татарстан бүлекчәсе 1923 нең мартында төзелә. 1924 нең октябрендә ТАССРда оешманың 9 меңнән артык кешене берләштергән 75 ячейкасы исәпләнә (җитәкчеләре Ф.Бурнаш, Ш.Усманов, Г.Кутуй).

*Н.А.Субаев.*

**РЕДИ́С** (Raphanus), әвернә чәчәклеләр семьялыгыннан берьеллык үләнчел кәбестә ыругы; чәчүлек торманың бер төре. Яшелчә культурасы, 2–3,5 *см* диаметрлы яссы түгәрәк яисә озынча конуссыман һәм орчыксыман формадагы, башлыча кызыл, ак, алсу һәм куе кызыл төстәге тамыразык. Тиз өлгерешле булуы б-н аерылып тора (чәчкәннән соң 20–25 көннән уңышы җыела), салкынга чыдам, туфракның уңдырышлылыгына һәм дымга таләпчән. Кыска көндә яхшы үсә. Орлыклары 3–4 °С темп-рада шытып чыга, үсү өчен иң яхшы темп-ра 15–18 °С. Орлыкларын 1 $м^2$ га 2,5–3 *г* (1 *га* га 25–30 *кг*) исәбеннән чәчәләр, уңышын сайлап-сирәкләп җыялар. Азык буларак яңа өлгергән, эшкәртелмәгән килеш кулланыла. Татарстанда чәчәргә тәкъдим ителгән сортлары: «Вюрцбургский 59» (1964), «Красный Великан» (1964), «Рубин» (1987), «Жара» (1988), «Дунганский 12/8» (1993), «Заря» (1993), «Стойкий» (1998). Редис чәчүлекләренә иң зур зыянны кәбестә борчалары китерә. Р., нигездә, йорт яны бакчаларында һәм аз күләмдә зур яшелчә хуҗалыкларында үстерелә.



*Әд.:* С а з о н о в а Л.В. П и в о в а р о в а Н.С., М а н т р о в а Э.Г. Редис, редька, репа, брюква. Л., 1986.

*И.Н.Афанасьев.*

**РЕДУ́КЦИЯ**, т е л б е л е м е н д ә, авазның, әйтелеш озынлыгы кыскару яки киеренкелеге йомшаруга бәйле рәвештә, артикуляцион һәм акустик яктан үзгәрүе. Р. күренеше күбесенчә сузык авазларга хас, ш.у. тартыклар Р.се һәм катлаулырак авазлар тезмәсе (иҗекләр, сүзләр) Р.се дә очрый. Сыйфат Р.сен (авазның үзенә хас характерлы билгеләрен, сыйфатын үзгәртеп кыскаруы) һәм сан Р.сен (басымсыз иҗектәге сузыкларның кыска әйтелүе) аерып карыйлар. Татар телендә, нигездә, сан Р.се үсеш алган, бу очракта сузык авазның төп сыйфатлары саклана, бары тик аның көче һәм озынлыгы гына үзгәрә: мәс., ылыслы [ы̆лы̆слы́], кечкенә [кĕчкĕнә́], борылып [бŏрŏло́п] һ.б. Сан редукциясе тулы (авазның төшеп калуы) һәм өлешчә (авазның кыскаруы) була. Татар телендә еш кына — тулы Р. (сеңел — сеңлем [сеңлем́], барысы [ба́рсы]), сирәгрәк өлешчә Р. (дөреслә̆ү [дŏрŏслә́ү]) күзәтелә һ.б.

*Әд.:* С ә л и м о в Х.Х. Татар теле фонетикасы. Яр Чаллы, 1993; Татар грамматикасы. М.–К., 1998. Т. 1; С а ф и у л л и н а Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. К., 2001; С ө н г а т о в Г.М. Татар теленең фонетик закончалыклары. К., 2001; С а ф и у л л и н а Ф.С., З ә к и е в М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006.

**РЕЖИССЁРЛЫ́К СӘНГАТЕ́**. Театраль иҗатның сәнгатьчә эшләнешле бербөтен сәхнә әсәре тудыруны максат иткән мөстәкыйль бер төре; нигездә 20 йөздә формалаша. 19 йөз буена диярлек спектакльләрне сәхнәгә актёрлар яки антрепренёрлар куя, аларның эшчәнлекләре сәхнәне бизәү өчен кирәкле чаралар табу һәм актёрларга кайбер күрсәтмәләр бирү б-н чикләнә. Шулай да П.М.*Медведев* иҗатында режиссураның яралгы формалары ачык күренә башлый: ул күмәк башкаруга, актёрларның сәхнә тормышының чынбарлык б-н ярашуына, теге яки бу рольне уйнаганда тормышчанлыкка, сәнгатьчәлеккә ире-

шергә омтылуда чагыла. 19 йөз ахырында М.М.*Бородай* антрепризасы вакытында труппаның иҗади составында режиссёр вазифасы мөстәкыйльлеккә ирешә. Бородай труппасында эшләгән режиссёрлар Э.Г.Лясс, М.Ф.Рюмин, П.П.Ивановский үз бурычларын актёрлар б-н пед. эшчәнлек алып баруда, рольнең эзлекле башкарылуын тәэмин итүдә күрәләр. Мәскәү художество театрын нигезләүчеләрдән зур тәҗрибә алган Н.И.Собольщиков-Самарин үзенең режиссёрлык вазифасына күпкә тирәнрәк төшенә. Шулай да 1920 елларга кадәр Казан театрында режиссура үзенең бурычын, нигездә, спектакльләрдә әйдәп баручы рольләрне башкарган аерым актёрлар иҗаты өчен генә уңай шартлар тудыруда күрә. Эшли башлаган елларында татар театры режиссурасы да шундый ук халәт кичерә. Спектакльләрне сәхнәгә куюо б-н труппаның әйдәп баручы актёрлары шөгыльләнә, алар, нигездә, драматургларның — пьесалар авторларының күрсәтмәләренә нигезләнеп эшлиләр. И.Кудашев-Ашказарский, Г.Кариев, С.Гыйззәтуллина-Волжская, В.Мортазин-Иманский, З.Солтанов, Ш.Шамильский, К.Тинчурин, рус театры тәҗрибәсенә таянып, матди яктан ярлы булу сәбәпле, шартлы сәнгатьчә сурәтләү чараларыннан мәҗбүри файдаланып, әмма тормыш хакыйкатеннән читкә тайпылмыйча эшлиләр. 1920 елларда режиссура үсешенә сәнгатьтәге «сул» агымнар (*ТАТЛЕФ, СУЛФ*) зур йогынты ясый. 1923 тә Казанда барлыкка килгән, үзенең иҗаты б-н рус театрына да, татар театрына да билгеле бер дәрәҗәдә йогынты ясаган *КЭМСТ* театрында режиссура үзенчәлекле мәгънәгә ия була. КЭМСТ спектакльләренең стилистикасына хас аермачык идея юнәлеше, образлар бирелешендә плакатлылык, мизансцена күренешенең динамикасы, төсләр символикасы спектакльләрнең төп өлешләре булып тора. Алар спектакльләргә бөтенлек бирә, тулыландыра һәм тәэсирле итә. Режиссура фронт театрлары, эшче яшьләр театрлары (ТРАМ), «Зәңгәр блуза» («Синяя блуза»), «җанлы газета», театральләштерелгән массачыл бәйрәмнәр тәҗрибәсе хисабына байый. Мондый бәйрәмнәр арасында Казанда 1924 нең августында Беренче бөтендөнья сугышы башлануның 10 еллыгын билгеләп үтү аеруча зур әһәмияткә ия була. Инсценировка 1914–17 елгы вакыйгаларны колачлый; катнашучылар арасында — император Николай II, Распутин, Керенский, Родзянко һ.б., рольләрне башкаручылар — Казан гарнизоны кызылармиячеләре, хәрби-сәяси мәктәп тыңлаучылары, пр-тие эшчеләре, КЭМСТ актёрлары (барлыгы 10 меңгә якын кеше). Казан Зур драма театрында Л.Ф.Лазарев, С.Н.Воронов, А.Л.Грипич, И.А.Ростовцев кебек, Татар акад. театрында Г.Девишев, С.Вәлиев-Сульва кебек режиссёрларның иҗат эшчәнлекләре идея-образлы фикергә һәм аны тормышка ашыру өчен аеруча сәнгатьле сәхнә теле эзләүгә нигезләнә. Тормыш чынбарлыгыннан тайпылмаган хәлдә, режиссура сәнгатьчәлекнең шартлы образлы-символик чараларыннан кыю файдалана, сурәтләнә торган вакыйгаларны бирүдә масштаблы гомумиләштерүгә омтыла. Казан Зур драма театры сәхнәсендә «Яшенле яңгыр» («Гроза», А.Н.Островский; сәхнәгә куючы А.Л.Грипич), «Мещаннар» («Мещане», М.Горький; сәхнәгә куючы И.А.Ростовцев), «Ревизор» (Н.В.Гоголь) һәм «Гаепсездән гаепленләр» («Без вины виноватые», А.Н.Островский; икесен дә сәхнәгә куючы В.А.Чиркин), Татар акад. театры сәхнәсендә «Отелло» (У.Шекспир), «Банкрот» (Г.Камал; икесен дә сәхнәгә куючы С.Вәлиев-Сульва) кебек классик әсәрләрне сәхнәләштергәндә, иң элек социаль эчтәлек ачыла, сәхнә күренешләренең чикләре киңәя, вакыйгалар символик характер ала.

ВКП(б) ҮКның «Әдәбият-сәнгать оешмаларын үзгәртеп кору турында» (1932) карары, партия тарафыннан кабул ителгән һәм Мәскәү художество театрында гамәлдә булган совет чоры сәнгатендә соц. реализм ысулын раслау курсы режиссураның яңа сәнгатьчә чаралар эзләү мөмкинлекләрен чикли. 1930–50 еллардагы спектакльләр бердәм принцип — «тормышны нәкъ тормыштагыча чагылдыру принцибы» буенча куела. Көнкүреш хакыйкатенә натурализм дәрәҗәсендәге тугрылык спектакльләрнең сәнгатьчә чишелеш принцибы булып тора. Әмма шундый шартларда да сәхнә геройларының беренче чиратта рухи дөньяларына тирәнтен үтеп керүгә нигезләнгән истә калырлык спектакльләр иҗат ителә. Казан Зур драма театрында хезмәт куйган режиссёрлар А.Д.Треплев, Б.С.Великанов, Б.Э.Ниренбург, Е.Г.Гаккель, Е.А.Простов, Л.М.Литвинов, Н.А.Медведев, Ә.М.Бейбутов актёрлар б-н эшләүгә зур игътибар бирәләр, башкару бердәмлегенә ирешәләр. Драматург җиткерергә теләгән фикерне югары дәрәҗәдә ачарга омтылу, тарихи чорны гәүдәләндерүдә төгәллек һәм җентеклелек, образларны бирүдә психол. тирәнлек Н.В.Гогольнең «Ревизор» һәм «Үле җаннар» («Мёртвые души»), А.Н.Островскийның «Соңгы корбан» («Последняя жертва») һәм «Гаепсездән гаепленләр» («Без вины виноватые»), А.П.Чеховның «Өч сеңел» («Три сестры»), М.Горькийның «Тормыш төбендә» («На дне») һәм «Карт» («Старик»), Н.Ф.Погодинның «Кремль курантлары» («Кремлёвские куранты») һәм «Баһадирлар» («Третья патетическая»), А.Н.Толстойның «Газап чигеп йөрү» («Хождение по мукам»), Р.Ишморатның «Үлмәс җыр», М.Н.Елизарованың «Давыл хәбәрчесенең яшьлеге» («Юность буревестника»), А.Н.Афиногеновның «Үз балаларының әнисе» («Мать своих детей») һ.б. әсәрләр буенча идея-сәнгатьлелеге ягыннан масштаблы, тирән мәгънәле спектакльләр иҗат итәргә мөмкинлек тудыра.

Бу елларда Татар акад. театрында проф. режиссура ныгый. Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тының (ГИТИС) режиссёрлык бүлеген тәмамлаган Г.Г.Исмәгыйлев һәм Ш.М.Сарымсаковның эшчәнлеге спектакльне сәхнәгә кую культурасының үсешенә һәм аның барлык өлешләрен төгәл оештыруга, идея-сәнгатьчә фикер нигезендә бербөтен сәхнә әсәре иҗат итүгә юнәлтелгән була. Бу елларның аеруча әһәмияткә ия тирән эчтәлекле спектакльләре — «Чаткылар», «Ташкыннар» (Т.Гыйззәт), «Шәмсекамәр» (М.Әблиев), «Тукай» (Ә.Фәйзи), «Зифа» (Н.Исәнбәт), «Җилкәнсезләр» (К.Тинчурин). Алар татар театрының югары проф. дәрәҗәсен билгели, аның җитди иҗади бурычларны хәл итәргә сәләтле булуын күрсәтә. Психол. реализм юнәлешендә ш.у. К.Җ. һәм Р.Р.Тумашевлар, Г.Ф.Йосыпов, С.Г.Өметбаев, Р.Г.Абдуллаев, З.Х.Туишева, Л.Г.Садриев кебек режиссёрлар да эшли. Милли драматургия спектакльләре, нигездә, көнкүреш комедиясе һәм драмасы формасында бирелә. 1930 еллардагы кайбер идеологик күрсәтмәләрне 1960 та башланган яңадан карау, В.Э.Мейерхольд, Е.Б.Вахтангов, А.Я.Таировларның иҗат мирасын үзләштерү Р.с.нең алга таба үсешенә, яңа сәнгатьчә сурәтләү алым-чаралары б-н баюына ярдәм итә. Казан Зур драма театры сәхнәсендә Н.Ю.Орлов, С.Е.Ярмолинец, В.М.Портнов, Э.М.Митницкий, Н.И.Басин, Е.Д.Табачников, татар театрында П.Н.Исәнбәт, Р.Ә.Бикчәнтәев, М.Х.Мостафин, Г.К.Хөсәенов спектакльләрендә режиссураның өстенлеге ачык сизелеп тора; актёрлар иҗаты режиссёрларның теге яки бу спектакльгә карата күрсәтмәләре б-н билгеләнә. Режиссёрның театрда спектакльне сәхнәгә куючы буларак та, иҗат коллективын тәрбияләүче буларак та әһәмиятле роле М.Х.*Сәлимҗановның* Татар акад. театрындагы эшчәнлегендә ачык чагылыш таба. М.Х.Сәлимҗанов иҗатына хас булган шартлылык б-н тормышчанлыкның, Европа театры алымнары б-н татар сәнгатенең фольклор, ш.и. йола формаларының табигый үрелеп баруы татар театрының Р.с.н билгеле бер дәрәҗәдә баетып кына калмый, хәзерге дөнья театры үсешенә дә йогынты ясый. Р.с. үсешендә М.Х.Сәлимҗанов биргән юнәлешне — теге яки бу спектакльне иҗат итү процессында режиссёрның төп рольне башкаруы, рәссам-иҗатчы буларак сүз ирегә, фикер хөрлегенә ия булуы, теге яки бу мәсьәләгә карата үз карашларын кыю җиткерүе — иҗатларында Ф.Р.Бикчәнтәев, Р.М.Заһидуллин, Р.М.Әюпов, Ф.М.Ибраһимов, Б.Ф.Бәдриев һ.б. дәвам итә.

*Әд.:* Татар театры (1906–1926). К., 2003; Илялова И. Г.Камал театры артистлары — Артисты театра им. Г.Камала: Биогр. белешмәлек. К., 2005; Крути И. Русский театр в Казани. М., 1958; Илялова И. Театр имени Камала. К., 1986; шул ук. Театр имени Тинчурина. К., 2002; Илялова И., Ингвар И. Русский театр в Казани. К., 1991; Арсланов М.Г. Татарское режиссёрское искусство (1906–1941). К., 1992; шул ук. Татарское режиссёрское искусство (1941–1956). К., 1996; шул ук. Татарское режиссёрское искусство (1957–1990). К., 2002; Благов Ю. «... получил прозвище Казанский». К., 2001; шул ук. Казанская антреприза Собольщикова-Самарина. К., 2004; шул ук. КЭМСТ и театральная жизнь Казани 1920-х гг. К., 2005.

*Ю.А.Благов, И.И.Илялова.*

**РЕЗВЯКО́В** Николай Павлович (7.1.1942, Алабуга р-ны Танай а. — 25.5.1987, Казан), гистолог, мед. фән. д-ры (1981), проф. (1986). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1969), Алабуга р-ны Кокшан участок хастаханәсендә баш табиб. 1970 елдан Казан мед. ин-ты-

ның — гистология, 1985 тән гистология һәм эмбриология кафедраларында, бер үк вакытта, 1975 тән, педиатрия ф-ты деканы урынбасары, 1983 тән дәвалау ф-ты деканы. Хезмәтләре мускулларның кыскаручанлыгын көйләүне өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Морфометрическая и гистохимическая характеристика портняжной мышцы лягушки в онтогенезе // Архив анатомии, гистологии и эмбриологии. 1979. Вып. 5; Исследование роли цитостатиков в патогенезе нейро- и миопатий // Биол. науки. 1981. № 9 (автордаш).

*Әд.:* Деканы Казанского медицинского университета: Биогр. словарь деканов Казан. гос. мед. ун-та. К., 1997.

**РЕЗВЯКО́В** Николай Петрович (7.4.1885, Тверь губ. Заречье а. — 20.4.1948, Казан), физиолог, биол. фән. д-ры (1935), проф. (1935). Петербург ун-тын тәмамлаганнан соң (1911), шунда ук эшли. 1929–31 елларда Коммунистик академия каршындагы Мәскәү югары нерв эшчәнлеге ин-тында, 1931–38 дә Смоленск мед. ин-тында, бер үк вакытта Иваново мед. ин-тының физиол. каф. мөдире. 1938 дән Казан ун-ты физиол. каф. мөдире. Хезмәтләре нерв һәм мускул тукымалары физиологиясенә карый. Р. оптимум, пессимум, парабиоз проблемаларын өйрәнә. Парабиоз стадиясе буларак, патологик процессны (ялкынсыну, анафилаксия, аллергия һ.б.) тикшерә, авыруларны дәвалау өчен антипарабиотик чаралар куллануны тәкъдим итә. Бөек Ватан сугышы елларында Р. җитәкчелегендә яраларны, пешкән урыннарны тиз арада төзәтү һәм тире авыруларын дәвалау өчен винилбутил эфирын һәм аның полимерын куллануның нәтиҗәлелегé өйрәнелә, яраларны сыек тампон куеп дәвалау тәкъдим ителә.

Х е з м.: Изучение токов действия при посредстве катодного усилителя // Рус. физиол. журн. 1927. Т. 10, вып. № 1; Электрофизиологические исследования // Успехи биологической науки в СССР за 25 лет. М.–Л., 1945.

*Әд.:* Казанская физиологическая школа на рубеже веков. К., 2001.

*Н.В.Звёздочкина.*

**РЕЗЕДА́** (Reseda), резедачалар семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 60 ка якын төре билгеле, Евразиядә, Төньяк Африкада, башлыча, Урта диңгез буенда таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — сары Р. (R. lutea) Идел алдында һәм Көнчыгыш Кама аръягында очрый. Карбонатлар чыгып торган урыннарда, тимер юл өемнәрендә, юл буйларында, ара-тирә чүп үләне буларак кырларда үсә. 30–50 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамыр системасы юанрак төп һәм нечкәрәк ян тамырлардан тора. Сабагы ботаклы. Яфраклары чиратлашкан, каурыйсыман-телемнә. Чәчәкләре вак, аксыл яки яшькелт-сары, озын чукларга җыйналган. Җимеше — өч кырлы озынча тартмачык. Май — сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре июль — октябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Яфракларында С витамины, орлыкларында эфир мае бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе тир чыгару һәм бәвел кудыру чарасы буларак кулланыла. Ак чәчәкле хуш исле Р.не (R. odorata) декоратив үсемлек буларак бакчаларда үстерәләр. Баллы үсемлекләр.

**РЕ́ЗНИК** Александр Ефимович (22.6.1916, Одесса ш. — 27.10.1979, Казан), инфекционист, мед. фән. д-ры (1963), проф. (1964), ТАССРның атказ. табибе (1964). Одесса мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1939), Украина ССР Курортлар идарәсендә эшли. 1941 елдан Казан шәһәре 2 нче йогышлы авырулар хастаханәсендә, баш табиб (1942–56); бер үк вакытта Казан мед. ин-тында, 1958 дән йогышлы авырулар каф. мөдире. ТАССРның баш инфекционисты (1972–74). Хезмәтләре йогышлы авырулар патогенезын өйрәнүгә һәм патогенетик терапия мәсьәләләренә карый. ТАССР Инфекционистлар җәмгыяте рәисе (1958–79). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Диагностика стёртых форм скарлатины // Педиатрия. 1955. № 6; Клиника и лечение гриппа // Казан. мед. журн. 1957. № 2/3; Нарушение двигательной функции толстого кишечника у больных острой дизентерией // Казан. мед. журн. 1973. № 3 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Александр Ефимович Резник: Некролог // Казан. мед. журн. 1980. № 1.

**РЕ́ЗНИК** Владимир Саввич (16.8.1937, Хабаровск ш.), химик-органик, химия фән. д-ры (1987), проф. (1993), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1978). ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2014). 1959 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1963 тән РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, химик-биол. тикшеренүләр лаб-ясе мөдире (1980 нән), директор урынбасары (1992 дән). Хезмәтләре азотлы гетероцикллар химиясенә, физиол. актив кушылмалар синтезына карый. Р. N-алкил чылбырында төрле алыштыргычлары булган N-алкилоксигидропиримидиннарны синтезлау юлларын эшли. 1- һәм 3-(омега-галогеналкил)урацилларның химик тотышындагы аерымлыкларны тикшерә. Беренче булып урацилфосфатларны синтезлый һәм аларның үзлекләрен өйрәнә. Составларында пиримидин боҗралары булган макроцикллар табу юлларын тәкъдим итә. Диуцифон һәм ксимедон дару препаратларын эшли һәм җитештерүгә кертә. Уйлап табуга 87 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Некоторые аспекты взаимодействия N-(омега-галогеналкил)урацилов с нуклеофильными реагентами // Журн. орган. химии. 1993. Т. 29, вып. 10 (автордаш); Реакционная способность 2-(омега-галогеналкилтио)пиримидинов. Вклад процессов циклизации // Журн. орган. химии. 1993. Т. 29, вып. 11 (автордаш); Ксимедон в клинической практике. Н.Новгород, 2001 (автордаш).

**РЕ́ЗУС-ФА́КТОР** (маймылларның Macacus rhesus төре аталышыннан), кешедәге эритроцитларның, аларда «резус» антигеннары (изоантигеннар) булу-булмауга бәйле рәвештә, тумыштан килгән төркем үзлеге. Нәселдән күчә, гомер буена үзгәрешсез кала, канның башка системалары үзенчәлекләренә бәйле түгел. Кешеләрнең 85% ында кан уңай резуслы (Rh+), калганнарында тискәре резуслы (Rh-) була — ягъни канның резус-факторы булмый. Тискәре резуслы реципиентка уңай резуслы кан салганда, иммун антитәнчекләр барлыкка килергә, ягъни тулы булмаган яки тулы формадагы антирезус халәте туарга мөмкин, ә бу эритроцитларның таркалуына һәм шуңа бәйле реакцияләргә яки катлаулану очракларына (резус-конфликт) китерә. Резус-конфликтны кисәтү өчен, каны тискәре резуслы реципиентка фәкать тискәре резуслы кан салалар; кан салыр алдыннан, каннарның үзара ярашлылыгын АВО кан төркемнәре буенча гына түгел, Р.-ф. буенча да тикшерәләр. Авырлы хатыннарда, әгәр тискәре резуслы канга ия яралгы атасының Р.-ф.ын алган булса, резус-конфликт килеп чыгу ихтималы бар. Яралгының Р.-ф.лы эритроцитлары аз гына микъдарда плацента аша ана канына күчәргә мөмкин. Шуның нәтиҗәсендә ана организмында резус-антитәнчекләр барлыкка килә, алар, плацента аша яралгы канына күчеп, анда гемолиз халәте тудыралар; тора-бара яралгыда һәм яңа туган балада гемолитик авыру башлана. Беренче йөклелектән туган балада, гадәттә, әлеге авыру күзәтелми. Антитәнчекләрнең иң югары тупланышы бала туар алдыннан була. Авырлы вакытта, катлауланулар булдырмау йөзеннән, хатын-кызлар каннарында Р.-ф. булу-булмауны тикшертергә тиеш; бар дип табылган очракта, махсус булмаган гипосенсибилизация чаралары үткәрелә.

Р.-ф. проблемалары Казан галимнәре тарафыннан 1950 еллардан бирле Казан мед. ун-тының 1 нче акушерлык һәм гинекология кафедрасында өйрәнелә. Б.Г.Садыйковның «Ана һәм яралгы каннарының резус Rh һәм АВО ярашмавына, яңа туган балаларда гы гемолитик авыруга диагноз кую һәм авыруларны дәвалау» («Диагностика и лечение резус Rh и АВО несовместимости крови матери и плода и гемолитической болезни новорожденных», 1965), «Резус-конфликтлы йөклелек һәм гемолитик авыру комплекслы иммун-биохимик тикшеренүләр яктылыгында» («Резус-конфликтная беременность и гемолитическая болезнь в свете комплексных иммунобиохимических исследований», 1974) хезмәтләре, профессорлар П.С.Гуревич һәм И.А.Осипов катнашында «Перинаталь чор гемолитик авырулары» («Гемолитические болезни перинатального периода», 1977) китабы дөнья күрә. 1978 дә «Яңа туган балаларда гемолитик авыру» («Гемолитическая болезнь новорождённых») мәкаләләр җыентыгы басылып чыга. Д.П.Игнатьева фәнни экспериментлар уздыра һәм тикшеренү нәтиҗәләренә «Яралгыда һәм яңа туган балаларда гемолитик авыру» («Гемолитическая болезнь плода и новорождённых», 1988) хезмәте б-н йомгак ясый. Казан мед. ин-ты хезмәткәрләре тарафыннан «Перинатология мәсьәләләре» («Вопросы перинатологии», 1989) монографиясе нәшер ителә. Р.-ф.ны өйрәнү мәсьәләләре Халыкара акушер-гинекологлар симпозиумында (1973), бөтенсоюз симпозиумнарында (1970–80 еллар), Халыкара Познань симпозиумында (Польша, 1980) карала. Фәнни тикшеренүләрнең нәтиҗәләре Казан мед. ин-ты һәм Казан мед. академиясе клиника һәм кафедраларында гамәлгә кертелә. 1965 елда ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка иммун-конфликтлы йөклелек үзәге булдырыла (хәзер Респ-ка клиник хастаханәсе каршында эшли).

*Б.Г.Садыйков, Д.П.Игнатьева.*

**РЕЙНБО́Т** (Резвой) Анатолий Анатольевич (4.2.1868, С.-Петербург — 1918), дәүләт эшлеклесе, генерал-майор (1906). Дворяннар катлавыннан. Михаил артиллерия уч-щесен (С.-Петербург, 1888), Генштабның Николай академиясен (С.-Петербург, 1895) тәмамлый. 1888 елдан хәрби хезмәттә. 1901–03 тә Финляндия генерал-губернаторы канцеляриясендә. Нюланд губернасының ланд-секретаре (вице-губернаторы). 1905–06 да Казан губернаторы. 1905 нең ноябрь–декабрь айларында хәрби отряд башында Казан губернасы өязләре буйлап крәстиян кузгалышларын бастырып йөри. 1905 нең 12 декабрендә аның боерыгы б-н Казанда с.-д. һәм эсерлар оешмасы тар-мар ителә. 1906–07 дә Мәскәү шәһәре башлыгы. 1909 да хакимияттән законсыз файдаланганы өчен Сенат судына бирелә, 1911 дә аклана. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша (1914–17).


А.А. Рейнбот.

*Әд.:* Дело бывшего московского градоначальника Рейнбота и его помощника Короткого. СПб., 1911; Падение царского режима: По материалам Чрезвычайной комиссии Временного правительства. М.–Л., 1927. Т. 7.

*Е.Б.Долгов.*

**РЕЛЬЕ́Ф**, тышкы күренеше, үлчәме, килеп чыгышы, яше, тарихи үсеше буенча төрле булган Бөтендөнья океаны төбе, Җир өсте тигезсезлекләре җыелмасы. Уңай (кабарынкы) һәм тискәре (батынкы) формалардан төзелә. Эндоген (эчке) һәм экзоген (тышкы) процессларның берьюлы җир өслегенә дәвамлы тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килә. Эндоген процесслар (җир кабыгының тектоник хәрәкәте) зур масштабтагы тигезсезлекләр барлыкка китерә, әлеге тигезсезлекләр, гадәттә, геол. структуралар б-н туры килә. Экзоген процесслар (агым сулар, диңгез дулкыннары, җил һ.б.ның геол. эшчәнлеге) өслекне җимерүгә һәм тигезләүгә юнәлгәннәр, тигезсезлекне кечерәк формалар б-н катлауландыралар.

Татарстан Р.ы денудацион калкулыклар катламының чиратлашуы б-н барлыкка килгән һәм аларның түбәнлекләрен бүлүче баскычлы тигезлектән гыйбарәт. Респ-ка терр-ясендә аеруча зур калкулыклар: *Бөгелмә яссы калкулыгы* (иң зур биеклеге 381 *м*), *Идел буе калкулыгы* (280 *м*), *Вятка увалы* (228 *м*), *Можга калкулыгы* (232 *м*), *Сарапул калкулыгы* (235 *м*). Барлык калкулык өслекләренең дә килеп чыгышына денудация хас, алар 3 төрле биеклектәге һәм төрле яшьтәге Р. баскычлары (плато) барлыкка китерәләр. Һәрбер түбәнрәк баскыч биегрәк ярусның өлешчә җимерелүе исәбенә хасил була. Бөгелмә калкулыгында гына сакланып калган югары плато (300–381 *м*) иртә неогенда барлыкка килә һәм Татарстан Р.ында иң борынгы элемент булып тора. Ул урта плато (180–240 *м*) өслегеннән 60–80 *м* биеклектәге киртләч б-н аерыла, плато исә соңгы эоплейстоценда формалаша һәм Идел б-н Кама алдында субүләрнең төп биеклеге булып хезмәт итә. Урта платоның авыш бусагалары урыны б-н салмак кына неоплейстоценда барлыкка килгән һәм Татарстанда аз таралган түбән платога (140–160 *м*) күчә. Кама аръягы түбәнлегенең һәм Кама-Агыйдел уйсулыгының абс. биеклекләре 150 *м* дан артмый; аларның өслекләре неоген-дүртенчел чорда елга, күл һәм диңгез аккумуляциясенең катлаулы тезмәсе нәтиҗәсендә формалаша, соңыннан алар денудациягә дучар була.

Калкулыклар һәм түбәнлекләр үлчәме, морфологиясе, яше буенча төрле-төрле елга үзәннәренең тыгыз челтәре б-н ергаланган. Идел, Кама, Вятка һәм күп кенә уртача зурлыктагы елгаларның үзәннәренә хас үзенчәлек булып Бэр законы буенча елга юлларының уң якка күчүе б-н бәйле планетар типтагы *сөзәклекләр асимметриясе* тора. Уңъяк яры текә, төп токымнардан тора, елга террасалары комплексы биләгән сулъяк яры сөзәк, алар неоген утырмалары б-н түшәлгән тирән эрозияле (200 *м* га кадәр) уемнарны каплый. Сөзәклекләр асимметриясе Каманың түбәнге агымында бөтен җирдә дә чагылмый, чөнки елга юлында үзгәрешләр булмаган.

Елга үзәннәренең киңлеге су агымы күләме б-н билгеләнә: иң зур киңлек Идел буе үзәненә хас (Татарстанның көньяк чигендә 90 *км* га кадәр), уртача зурлыктагы елгаларның түбән агымнарында 10 *км* дан артык түгел, күпчелек кече елгаларның 1–2 *км* дан сирәк арта. Шулай ук кече елга үзәннәре сөзәклекләре өчен неоплейстоценның салкын перигляциаль климат шартларында төрле экспозицияле сөзәклекләрдә экзоген процессларның (күбесенчә делювиаль-солифлюкцион) тигезсез тәэсире нәтиҗәсендә туган асимметрия хас. Рельеф барлыкка китерүче хәзерге заман экзоген процесслардан аеруча елга ярларының ашалуы, гравитацион авышлык (буалар кору, коелмалар, шуышмалар, крип), *карст* зур урын алып тора. Кешенең хуҗалык эшчәнлеге (беренче чиратта, урманнарны кисү һәм җирләрне сукалау) нәтиҗәсендә, урман һәм урман-дала ландшафтларына хас булмаган процесслар: яссылык һәм ерым эрозиясе, дефляция үсеш ала. Зур сусаклагычлар төзелү аларның ярларының абразияле-аккумулятив процесска дучар булуына китерә (к. *Абразия*), әлеге процесс сусаклагычлар тулганнан соң беренче елларда аеруча көчле була. Файдалы казылмалар табылган районнарда, шәһәрләрдә, төзелеш объектларында Р. шактый гына антропоген шартлы үзгәрешләр кичерә.

*Әд.:* Сементовский В.Н., Батыр В.В., Ступишин А.В. Рельеф Татарии. К., 1951; Дедков А.П. Экзогенное рельефообразование в Казанско-Ульяновском Приволжье. К., 1970; Овражная эрозия на востоке Русской равнины. К., 1990.

*В.В.Мозжерин.*

**РЕЛЬЕФНЫ́Ң АНТРОПОГЕ́Н ФО́РМАЛАРЫ**, кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә хасил булган җир өсте һәм җир асты рельеф формалары. Шулай ук еш кына техноген факторлар дип тә йөртелә. Татарстан терр-ясендә киң таралыш алган. Рельефның җир өсте формаларына төзелеш һ.б. чималлар чыгару карьерлары, ш.у. юл уемнары, өемнәр, дамбалар керә. Төзелеш вакытында шәһәрләрдә җир өслеге кисемнәре һәм грунтның таралуы күзәтелә. Йөзәр еллар дәвамында Казанда 15 *м* калынлыкта өелгән грунтлар барлыкка килә, күп кенә ерым-сыза формалары тигезләнә һәм күмелә. Рельефның җир асты формаларына Кама Тамагы р-нында гипс, Югары Ослан р-ны Печище авылы янында известьташ чыгару штольнялары керә. ТРда файдалы казылмаларны чыгару һәм төзелеш вакытында күчерелгән материалның еллык күләме якынча 5 млн. $м^3$ тәшкил итә.

**РЕМДИ́ЗЕЛЬ**, к. *КАМАЗ*.

**РЕМЕ́ННИКОВ** Алексей Михайлович (10.11.1918, Петроград — 24.12.2007, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1971), проф. (1973), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1941), Вологда өлкәсе мәктәпләрендә укытучы. 1950–2001 дә Казан пед. ун-тында, гомуми тарих каф. мөдире (1962–88). «Б.э.ның III йөзендә Төньяк Кара диңгез буе кабиләләренең Рим б-н көрәше» («Борьба племён Северного Причерноморья с Римом в III в. н. э.», М., 1954) монографиясе авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кадыров И.Х. К 80-летию Алексея Михайловича Ременникова // Вестн. древней истории. 1999. № 2.

*Р.Х.Әхмәтҗанов.*

**РЕ́МИЗОВ** Александр Борисович (13.10.1938, Мәскәү), химик-технолог, техник фән. д-ры (1981), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). 1961 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1981 дән Казан технол. ун-тында, югары уку йортларының оптик спектроскопия буенча фәнни-тикшеренү лаб-ясе мөдире, 1994 тән гомуми химик технология каф. профессоры. Хезмәтләре органик кушылмаларны физик-химик ысуллар б-н тикшерүгә карый. Р. күкерт- һәм фосфорорганик кушылмалар молекулаларының тирбәнү спектрларын һәм конформацияләрен өйрәнә, S, P һәм C атомнарының төрле торышында S-C, S-O, P-C һәм P-O бәйләнешләре тирәсендәге эчке әйләнүләрнең закончалыкларын билгели. Конформацион тигезләнешләр термодинамикасында компенсация эффектын ача. Кристалл үсеше параметрларының темп-рага һәм аслык структурасына бәйлелеген күзәтә. Конформацион тигезләнешләрнең термодинамик параметрларын эремәләрнең инфракызыл спектрларын тикшерү нигезендә билгеләү юлларын тәкъдим итә (биредә конформерлар — борылма яки геометрик изомерлар). Конформацион анализда кушылма чәчелүнең актив спектроскопиясе ысулын куллана. Инфракызыл спектрлардагы кайбер йотылу сызыклары дихроизмын чагыштыру юлы б-н молекуляр кристалларда молекула конформациясе төрен билгеләү алымын эшли. Полимер чыбыларның локаль хәрәкәтчәнлеген, пыяласыман полимерларның иреклe күләмен һәм икенчел релаксацион күчешләрен өйрәнү өчен яңа — конформацион зондлар

ысулын тәкъдим итә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Влияние межмолекулярных взаимодействий на внутреннюю динамику паразамещённых 1, 2-дифенилэтанов // Журн. физ. химии. 1990. Т. 64, № 4 (автордаш); Замораживание конформационной подвижности малых молекул (зондов) в стеклообразных полимерах и вторичные релаксационные переходы // Высокомолекулярные соединения. 2007. Т. 49, № 5 (автордаш); Internal rotation in 1,2-di-(pXC$_6$H$_4$)ethanes: infrared spectra and compensation effects // Spectrochimica. Acta. 2003. V. 59A, № 13 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**РЕ́МПЛЕР** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 28 *км* көнчыгыштарак, Казан — Түбән Новгород автомагистрале буенда. 2010 елда 225 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 44%, татарлар — 32%) яши. Башлангыч мәктәп. 1893 тә нигез салына. Беренче исеме — Ремплер хуторы. Халкы игенчелек, колмак үстерү, умартачылык б-н шөгыльләнә. Оештырылган көннән Казан губернасының Казан өязе Ильинка волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1920 дә — 168, 1926 да — 200, 1938 дә — 263, 1949 да — 162, 1958 дә — 292, 1970 тә — 313, 1979 да — 293, 1989 да — 244, 2002 дә — 190 кеше.

**«РЕНЕ́Т ПОВО́ЛЖЬЯ»** («Ренет Крюднера теньковский»), алмагач сорты, 1946 елда Тәмте җиләк-җимеш станциясендә Г.И.*Розанова* тарафыннан чыгарыла. «Ренет Крюднера» сортыннан ирекле серкәләндерелгән чәчкен. Салкынга чыдам, уңышы югары (1 алмагачтан 100 *кг* га кадәр). Кутыр авыруы б-н аз зарарлана. Агачы уртача биеклектә, уртача куелыктагы шарсыман ябалдашлы. Үсентеләре туры, нәзек, коңгырт, төксез күп санлы ясмыкчалары бар. Яфраклары зур түгел, түгәрәк, каты, ялтыравыклы төксез, куе яшел төстә, читләре вак каяулы. Җимеше вак һәм уртача (80–100 *г* га кадәр), түгәрәк-конуссыман, ачык сары төстә, аз гына алсулыгы бар, тәме әчкелтем баллы; сентябрь ахырында өлгерә, 6–7 ай саклана. Бу сорт Татарстанда 1956 елда районлаштырыла.

*В.А.Наумов.*

**РЕНТГЕНОЛО́ГИЯ**, нур ярдәмендә диагноз кую, клиник медицина өлкәсе, кешенең әгъза һәм системалар төзелешен һәм функцияләрен норма һәм патология халәтендә тикшерә, авыруларга диагноз кую өчен рентген нурларын куллану теориясен һәм практикасын өйрәнә. Нур терапиясе — төрле авыруларны, ш.и. яман шеш авыруларын ионлаштыручы нурларның биол. тәэсире нигезендә дәвалау ысуллары җыелмасы. Р.нең барлыкка килүе һәм диагноз куюда кулланыла башлавы немец галиме В.К.*Рентгенның* Х-нурлар (рентген нурлары) турында 1895 елда ясаган ачышы б-н бәйле. 1898 дә француз галимнәре — ирле-хатынлы Кюрилар тарафыннан ясалма радиоактивлык феномены ачыла, төрле радионуклидлар алына. Әлеге ачыш нур терапиясе үсеше өчен тизләткеч фактор булып тора һәм дистанцион нурланыш өчен радиоактив чыганаклы гамма-терапевтик аппаратлар булдыру мөмкинлеге бирә. Россиядә Р.не гамәлгә кертүнең башында А.С.Попов, В.Н.Тонков, А.К.Яновский, И.Р.Тарханов (1896) тора.

Казанда беренче рентген сурәте 1896 елда проф. П.И.Тихов тарафыннан алына; рентген нурлары Казандагы клиникаларда кулланыла башлый. 1907 дә А.Н.Казимбәк беренче рентген аппараты урнаштыра; 1908 гә Казанда Россиядә эшләнгән — 8, 1930 еллар уртасында 30 дан артык аппарат була. Профессорлар В.И.Разумовский, П.И.Тихов, Н.И.Котовщиков һ.б. төрле аномалияләр һәм эчке органнар авыруларына диагноз куйганда рентген нурланышы кулланалар. 1915 тә акушерлык-гинекол. клиникасында (1936 дан — В.С.Груздев исем.) «Рентген нурларының терлек аналыгына тәэсире» («Действие лучей Рентгена на матку животного») темасына фәнни эш башкарыла.

Мед. белгечлеге буларак, Р. 1920 еллар башында үсеш ала. 1927 дә — Казан рентгенологлар җәмгыяте (җитәкчесе — Р.Я.Гасуль), 1982 дән ТР Нур б-н диагноз куючылар ассоциациясе (җитәкчесе — М.К.Михайлов) оеша. Казан клиник ин-тының (1925 тән — ГИДУВ, 1995 тән — Казан мед. академиясе) эчке авырулар каф. каршында рентген кабинеты, аннары — рентген бүлеге ачыла, нур ярдәмендә дәвалау гамәлгә кертелә (җитәкчесе — М.И.Гольдштейн, 1927 дә Р. кафедрасы булдырыла (1953–67 елларда Р. һәм радиология кафедрасы). 1936 да Казан мед. ин-тында Р. курсы оештырыла. СССРда Р.гә караган иң беренче фәнни хезмәтләрнең берсе — «Ашказаны рентгенокимографиясе һәм аның яман шеш авыруларын ачыклаудагы әһәмияте» («Рентгенокимография желудка и её значение при распознавании раковых заболеваний», 1940) хезмәте М.И.Гольдштейн тарафыннан языла; 1952 дә авыруларны дәвалау өчен радиология лаб-ясе ачыла. ГИДУВның Р. кафедрасында рентгенотехникларның белемен күтәрү курслары эшли (1933–50).

Илдәге беренче томограф һәм томофлюорограф Казан ГИДУВының Р. кафедрасы рентген техникы В.А.Новиков тарафыннан конструкцияләнә (1936, үпкә томограммасы төшерелә). В.А.Новиков тагын 70 тән артык физиотерапевтик һәм рентген аппараты конструкцияли һәм камилләштерә. 1941–45 тә ГИДУВ Казан эвакуация госпитальләрендәге яралыларга хезмәт күрсәтү өчен хәрби рентгенологлар әзерли, ин-тта ш.у. төрле җәрәхәтләргә рентген кулланып диагноз кую ысуллары эшләнә. Кафедраның иң тәҗрибәле хезмәткәрләре Казан госпитальләренең Р. бүлекләрен җитәкли. Сугыш елларында 250 табиб һәм 180 нән артык рентген лаборанты әзерләнә. Профессорлар: Д.Е.Гольдштейн — яраларны дәвалаганда фистулография куллану, М.Х.*Фәйзуллин* — баш капкачы яраларына, А.Н.Кревер күкрәк читлеге яраларына рентген кулланып диагноз кую турында хезмәтләр бастыралар. 1960 та Казан мед. ин-тында проф. М.Ф.Мусин тарафыннан махсус артериография ысулы эшләнә (СССРда беренче буларак, артериография амбулатория шартларында уздырыла). Бу тикшеренүләр Респ-ка клиник хастаханәсендә кан тамырлары хирургиясе бүлеге ачылуга нигез була. Электрорентгенография ысулыннан файдалану һәм аны куллану буенча Респ-ка координация үзәге оештырыла. 1953–82 дә Казан ГИДУВының Р. кафедрасында (мөдире — М.Х.Фәйзуллин) яңа фәнни юнәлеш — нейрорентгенология үсеш ала. 1980 еллар башында, илдә беренче буларак, балаларда туу вакытында зарарланган үзәк нерв системасы проблемалары өйрәнелә, әлеге тайпылышларның классификациясе тәкъдим ителә, авыруның рентген ярдәмендә ачыкланган билгеләре клиник билгеләр б-н чагыштырыла (каф. мөдире — М.К.Михайлов). 1992 дә Казан ГИДУВының Р. һәм радиология кафедрасы нур ярдәмендә диагноз кую кафедрасы дип үзгәртелә; Төбәкара клиник диагностика үзәге, 2 нче Респ-ка клиник хастаханәсе һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы Респ-ка онкология клиник диспансеры кафедраның базаларын тәшкил итәләр. Травма җәрәхәтләре диагностикасы, баш миендәге кан тамырларының контраст булмаган магнит-резонанс ангиографиясе һәм нур б-н дәвалау мәсьәләләре И.И.Камаловның фәнни хезмәтләрендә карала; Г.И.Володина — бавыр авыруларына, И.А.Гыйләҗетдинов сөяк системасындагы шешләргә радионуклид диагностика ясау ысулларын тикшерәләр һәм гамәлгә кертәләр. Нур ярдәмендә диагноз куюда заманча яңа ысуллар: компьютер рентген томографиясе, магнит-резонанс томографиясе, ультратавыш ярдәмендә сканирлау кулланыла башлау медицинаның чиктәш дисциплиналары (онкология, эндокринология, неврология, гинекология һ.б.) интеграциясе киңәюгә юл ача. Казан галимнәре тарафыннан төрле орган һәм системалар (ашказаны-эчәк тракты, үт бүлеп чыгару һәм сидек-җенес органнары системалары) авыруларын, ш.у. яралгының үзәк нерв системасы үсешендәге аномалия очракларын тикшергәндә диагноз кую алгоритмнары; гиперплазия процессларын һәм эндометрийдагы яман шешне башлангыч чорында ачыклау критерийлары (М.К.Михайлов, Р.Ф.Әкбәров) эшләнә. Диагноз куюның заманча ысуллары гамәлгә кертелү патологик үзгәрешләрне операциягә кадәр күзәтеп бәяләү мөмкинлеге бирә. 2010 елга кадәр Казан мед. академиясе, 2 нче Респ-ка клиник хастаханәсе, Төбәкара клиник диагностика үзәге, Респ-ка онкология клиник диспансерында ультратавыш диагностикасы буенча 1 меңнән артык белгеч әзерләнә.

*Әд.:* Казанский ГИДУВ им. В.И.Ленина. 1920–1990. К., 1990; Казанская государственная медицинская академия. 1920–1995. К., 1997; М и х а й л о в М.К. Роль и методы лучевой диагностики в современных условиях. К., 2000.

*М.К.Михайлов, И.А.Гыйләҗетдинов.*

**РЕПЕ́ЕВ** Михаил Маркович (6.11.1917, Казан губ., Лаеш өязе Ташкирмән а. — 24.12.2001, Казан), хакимият эшлеклесе. Ка-

зан пед. ин-тын (1940), Чиләбе танк уч-щесен (1942) тәмамлый. 1934–36 елларда Юртыш башлангыч мәктәбендә (Дөбъяз р-ны), 1936–38 дә Пәрәү урта мәктәбендә (Лаеш р-ны) укыта. 1944–52 дә — КПССның Минзәлә, 1957–60 та Лаеш район ком-ты 1 нче секретаре. 1952–57 дә Эшче депутатларның Әгерҗе башкарма ком-ты рәисе. 1960–66 да КПССның Татарстан өлкә ком-ты секретаре; бер үк вакытта, 1963–66 да, ТАССР МС рәисе урынбасары — КПССның Татарстан өлкә ком-ты һәм ТАССР МСның Партия-дәүләт контроле ком-ты рәисе. 1966–83 тә ТАССР Халык контроле ком-ты рәисе. Р. эшчәнлеге вакытында халык контроле органнары барлыкка килә. Алар социаль-икътисади үсеш планнарын үтәүне контрольдә тоту буенча, дәүләт тәртибен бозуны, хуҗалык эшләрендәге тәртипсезлекләрне, дәүләт милкен урлауны һ.б.ны булдырмау өлкәсендә эш алып баралар. 1959–85 тә ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**РЕПЕЛЛЕНТЛА́Р** (лат. repellere — этәрү, куу), бөҗәкләр һәм талпаннарны куркыту сәләтенә ия химик матдәләр. Кешеләрне һәм хайваннарны буынтыгаяклылар тешләвеннән саклау һәм авыруларны кисәтү максатыннан кулланыла. Р.ның кайберләре инсектицид үзлекләргә ия. Препаратны тәннең ачык урыннарына сөртәләр яки сиптерәләр, марля капюшон, яулык, япма, оекбаш, перчатка, җиңсә яки башка әйберләргә сеңдерәләр, крем, паста, кершәнгә кушып сылыйлар. Талпаннардан саклану өчен комбинезонны яки башка өс киемен 200–250 *г* препарат б-н эшкәртәләр. Чалбар балагының аскы өлешен һәм күлмәкнең өске өлешен аеруча җентекләп эшкәртү зарур. Яшел тукыма кара тукымага караганда чебен-черкинең игътибарын азрак җәлеп итә. Битне-башны саклау өчен Р. сеңдерелгән саклагыч битлек кияләр. Препарат күз, борын, авызның лайлалы катламына эләккән очракта, ялкынсыну барлыкка килә; тәндә яра, ачык җәрәхәт, тырналган урыннар булганда ш.у. Р. кулланырга ярамый. Р.ны тиредән сабынлы су б-н юып төшерәләр. Тәннең ачык урыннарына сөртелгән препарат кешене чебен-черки, бөҗәк-талпан һөҗүменнән 2–3 сәгатькә саклый (Россиянең Урта полосасында диметилфталатның тәэсире — 2–5 сәгатькә, дала зонасында 1–2 сәгатькә җитә). Себердә һәм чебен-черки күпләп үрчи торган башка урыннарда Р.ны тәнгә сөртү ысулы ярдәмче саклану чарасы буларак карала. Киемне кюзол һәм диэтилтолуамид б-н эшкәртү кешене чебен-черкидән тулысынча коткара, диметилфталат һәм гексамид өлешчә саклый. Иң киң таралган Р.: диметилфталат, дид, кюзол, диметилтолуамид, бензимин һ.б. 1990–95 елларда Казан вет. медицинасы академиясе һәм Бөтенроссия фәнни-тикшеренү вет. ин-ты (Казан) галимнәре (Д.К.Червяков, Г.Ә.Кашафетдинов, В.А.Антипов, Т.В.Гарипов, Р.Н.Әхмәдиев һ.б.) тарафыннан яңа төр нәтиҗәле Р. — нефть химиясе синтезы продуктлары сульфонт һәм сульфоксидлар тәкъдим ителә.

*Ф.Г.Нәбиев.*

**РЕПЕРТУА́Р** (фр. repertoire), билгеле бер вакыт дәвамында театрда башкарыла торган әсәрләр җыелмасы (муз., драматик, эстрада); театрның идея-сәнгати юнәлешен чагылдыра. Казан театры эшли башлаган елларыннан ук Р.га җитди мөнәсәбәте б-н аерылып тора. Аның формалашуы антрепренёрларның коммерция мәнфәгатьләре, ш.у. халыкның мул тормышлы өлешенең ихтыяҗлары б-н сәхнәдә тормыш чынбарлыгын күрергә теләгән демократик карашлы тамашачының теләге арасында кискен көрәш шартларында бара. Алдынгы карашлы интеллигенция, Казан ун-ты профессорлары, Р.ның сәнгати дәрәҗәсен үстерүне таләп итеп, матбугат битләрендә еш кына чыгышлар ясыйлар. 18 йөз ахырында — 19 йөз башында рус сәхнәсен тутырган чит ил авторларының тәрҗемә яисә үзгәртеп эшләнгән пьесалары буенча спектакльләр б-н беррәттән, Казан театры киң җәмәгатьчелек басымы б-н рус авторларының көнүзәк иҗтимагый проблемаларны күтәргән, наданлыкны, ришвәтчелек, бюрократия, социаль тигезсезлекне фаш иткән, гаделлекне, ирек сөю, ватанга мәхәббәтне данлаган пьесалары буенча да спектакльләр куя. Р.ның нигезен А.П.Сумароков, Я.Б.Княжнин, Д.И.Фонвизин, А.И.Крылов, А.И.Писарев, В.А.Озеров, П.А.Плавильщиков пьесалары тәшкил итә. 19 йөз башында Р.ның шактый урынын алып торган муз. спектакльләр арасында А.О.Аблесимов һәм М.А.Матинский әсәрләре аеруча популяр була. 1834 елда Казан сәхнәсендә һәвәскәрләр тарафыннан беренче тапкыр А.С.Грибоедовның «Акыллылык бәласе» («Горе от ума») комедиясе куела, 1836 да Казан шәһәр театры Р.ына кертелә. Эчке эшләр министры тарафыннан Казан губернаторы адресына юлланган тыюга карамастан, пьеса Казанда 1839 да (Фамусовны М.С.Щепкин уйный), 1840–50 дә сәхнәләштерелә; 19 йөзнең 2 нче яртысыннан бу спектакль ел саен куела. 1836 да — Казанда провинция сәхнәсендә беренче тапкыр — М.С.Щепкин Н.В.Гогольнең «Ревизор» комедиясен куя (шул вакыттан алып, әлеге спектакль Казан театры сәхнәсеннән төшми уйнала). 1853 тән Казан театры Р.ында шактый урынны А.Н.Островский пьесалары алып тора, аларның кайберләре, ш.и. «Төшемле урын» («Доходное место», 1857), «Урман» («Лес», октябрь, 1871) әсәрләре буенча спектакльләр беренче тапкыр биредә дөнья күрә. А.Ф.Писемский, А.В.Сухово-Кобылин, А.К.Толстой, И.С.Тургенев пьесалары буенча спектакльләр бер үк вакытта Казан һәм башкала театрларында уйнала. 1838 дә Казанда В.Г.Белинскийның «Сәер чир» («Странная болезнь»), 1895 тә С.В.Ковалевская һәм А.К.Лефлёрның «Бәхет өчен көрәш» («Борьба за счастье») пьесалары буенча спектакльләр куела; башка провинция сәхнәләрендә алар куелмый диярлек. 1890 елларда Л.Н.Толстой, А.П.Чехов, А.И.Сумбатов-Южин, В.И.Немирович-Данченко пьесалары, Ф.М.Достоевский әсәрләренең инсценировкалары Р.да төп урынны алып тора; 20 йөз башында аларга М.Горький һәм Л.Н.Андреев пьесалары да өстәлә. Казан театры антрепренёрлары үз Р.ына еш кына М.И.Верёвкин («Шулай тиеш» — «Так и должно», «Төп-төгәл» — «Точь-в-точь»), А.А.Фукс («Җирсез утар» — «Безземельное имение»), П.И.Фелонов («Гаепсездән гаепле» — «Без вины виноватая»), М.Л.Мандельштам («Кем хаклы?» — «Кто прав?»), Н.Ф.Юшков («Смеляночка»), К.К.Бродовский («Яшен тими узып китте» — «Гроза прошла мимо»), В.М.Ключников («Авылдагы ыгы-зыгы» — «Деревенские переполохи»), С.В.Дьяченко («Яшьлек гөнаһлары» —




Казан шәһәр театрының репертуар афишасы. 1909.

«Грехи юности», «Көч саламны да сындыра» — «Сила солому ломит»), Е.Ю.Геркен («Бөек Калиостро» — «Великий Калиостро», «Пыяла бүлемнәр» — «Стеклянные перегородки», «Алар яраттылар» — «Они любили») кебек җирле авторларның пьесаларын, ш.у. П.Д.Боборыкин, С.А.Найдёнов, Е.Н.Чириков, Н.Я.Шестаковның гомумроссия күләмендә танылу алган пьесаларын кертәләр. Чит ил драматургиясеннән Казан театры Р.ына кергән В.Дюканж, А.Дюма, В.Сарду мелодрамалары б-н беррәттән У.Шекспир, Ж.Б.Мольер, Ф.Шиллер, П.Кальдерон, Лопе де Вега пьесалары да шактый урын алып тора; И.В.Гётеның «Фауст», Софоклның «Әдип хөкемдар» («Эдип-царь») пьесалары буенча спектакльләр, 19 йөз ахырында Г.Гауптман, Г.Ибсен, Г.Зудерманның көнүзәк иҗтимагый проблемаларны күтәреп чыккан пьесалары, М.Метерлинк, А.Шницлер, Г.Д'Аннунционың символистик пьесалары буенча спектакльләр куела.

Совет чорында, 1980 еллар ахырына кадәр, Р. формалашу процессы партия органнарының көчле күзәтүе астында бара. Театрлар ВКП(б)-КПСС ҮКның «Әдәбият-сәнгать оешмаларын үзгәртеп кору турында» (1932), «Драма театрлары репертуары һәм аны яхшырту чаралары турында» (1946) ка-

рарларына нигезләнергә тиеш була. Р. Главполитпросвет, Сәнгать эшләре идарәсе, Мәдәният министрлыгы тарафыннан раслана. 1920 еллардан башлап, Казан Зур драма театры Р.ында заманча совет пьесасы өстенлек ала. 1923 тә — В.В.Маяковскийның «Мистерия-буфф», 1924 тә — А.В.Луначарскийның «Канцлер һәм слесарь» («Канцлер и слесарь»), 1925 тә — А.М.Файконың «Люль күле» («Озеро Люль») һәм Б.С.Ромашовның «Кабарып пешкән бәлеш» («Воздушный пирог»), 1926 да — Н.Р.Эрдманның «Мандат» һәм Б.С.Ромашовның «Криворыльскның бетүе» («Конец Криворыльска»), 1927 дә




Г. Девишев җитәкчелегендә Татар театр техникумында белем алучыларның гастроль репертуары афишасы («Казан кызы», Ф. Әмирхан; «Балдызкай», Г. Кутуй; «Татар авылы тормышыннан», М. Зәетов). Җәй. 1927.

М.А.Булгаковның «Зойка фатиры» («Зойкина квартира») әсәрләре буенча спектакльләр куела. Алдагы елларда Казан театры сәхнәсендә В.В.Вишневский, Н.Ф.Погодин, А.Н.Афиногенов, А.Н.Арбузов, Л.М.Леонов, А.М.Володин, И.М.Дворецкий, А.В.Вампилов, А.И.Гельман әсәрләре буенча спектакльләр дөнья күрә, чит ил драматургиясе Э. де Филиппо, У.Гибсон, Б.Брехт, Н.Саймон, Э.Олби, Ю.О'Нил, Ф.Дюрренматт әсәрләре б-н тәкъдим ителә.

Татар театры Р.ы иң элек 19 йөз ахыры — 20 йөз башында яшәп иҗат иткән берничә татар драматургы, аерым алганда, Г.Ильяси, Ф.Халиди, Г.Камал, Г.Исхакый пьесаларыннан, ш.у. төрек һәм әзәрб. авторлары Н.Кәмал, Н.Нариманов, А.Ахвердов, рус һәм чит ил авторлары әсәрләрен, аерым алганда, А.П.Чехов водевильләрен, Н.В.Гоголь, А.Н.Островский, Ж.Б.Мольер һәм Һ.Һейне пьесаларын иреклe үзгәртеп эшләү һәм рус теленнән тәрҗемә итү юлы б-н формалаша. Алдагы елларда Р. татар театры өчен язучы авторларның артуы хисабына үсә. Театр, авторлар б-н актив рәвештә элемтәдә торып, пьесалар иҗат итүгә зур өлеш кертә; күп кенә драматурглар, ш.и. К.Тинчурин, Т.Гыйззәт, соңрак Р.Ишморат, Т.Миңнуллин, Р.Батулла актёрлар мохитеннән үсеп чыга. Татар театры эшли башлауның беренче унъеллыгында, нигездә, социаль-әхлакый мәсьәләләрне, мәдәни торгынлык, наданлык, иске патриархаль традицияләр б-н көрәш проблемаларын үзәккә алган Р.ның тематик эчтәлеге алга таба иҗтимагый тормышның Окт. рев-циясе, Гражданнар сугышы, коллективлаштыру, Бөек Ватан сугышы, сугыштан соңгы төзелеш б-н бәйле әһәмиятле вакыйгаларын чагылдыра башлый. Ш.Усманов («Канлы көннәр», «Беренче адым», «Бай кызы»), Г.Ибраһимов («Яңа кешеләр»), Ф.Сәйфи-Казанлы («Дошманнар») пьесалары халыкның рухи үсешен гәүдәләндерә. К.Тинчурин («Американ», «Җилкәнсезләр»), Н.Исәнбәт («Һиҗрәт») пьесалары сатирик үткенлеге һәм вакыйгаларны киң колачлавы б-н аерылып тора. Аларда иске тормыш һәм дөньяга карашның рев-ция тарафыннан җимерелүе темасы ачыла. Т.Гыйззәт («Таймасовлар», «Чын мәхәббәт»), Н.Исәнбәт («Мәрьям»), М.Әмир («Тормыш җыры», «Миңлекамал») пьесаларында сугыш еллары вакыйгалары гәүдәләнеш таба. Театр Р.да жанрлар төрлелегенә омтыла. Комп. С.Сәйдәшев б-н иҗади берлектә муз. драма һәм комедия («Наёмщик», Т.Гыйззәт; «Зәңгәр шәл», «Сүнгән йолдызлар», К.Тинчурин) барлыкка килә, Н.Исәнбәт («Миркәй белән Айсылу», «Хуҗа Насретдин», «Идегәй»), Ә.Фәйзи («Тукай») пьесаларында тарихи-фольклор материалы чагылыш таба. Сугыштан соңгы елларда татар театры Р.ы иҗатларында чорның актуаль проблемаларын күтәреп чыккан А.Гыйләҗев, Ш.Хөсәенов, Х.Вахит, И.Юзеев, Т.Миңнуллин, Д.Вәлиев кебек драматургларның пьесалары б-н тулылана. Хәзерге татар театры Р.ын алар б-н беррәттән И.Зәйниев, Ф.Бүләков, З.Зәйнуллин, Д.Салихов, Р.Сәгъди, Р.Зәйдулла, Р.Батулла, И.Мәхмүтова, З.Хәким, М.Гыйләҗев, Н.Гыйматдинова, Ш.Фәрхетдинов, С.Юзеев, Н.Гаетбай һ.б.ның сәхнә әсәрләре тәшкил итә.

Татар драматурглары пьесалары б-н беррәттән татар театры Р.ында даими рәвештә рус һәм дөнья классикасы да урын ала. Театр күп тапкырлар Н.В.Гоголь, А.Н.Островский, А.П.Чехов, М.Горький, У.Шекспир, Ж.Б.Мольер, К.Гольдони, К.Гоцци, П.Бомарше, Лопе де Вега пьесаларына мөрәҗәгать итә. Р.га А.Н.Афиногенов, В.М.Киршон, А.Н.Арбузов, К.М.Симонов, Л.М.Леонов, Б.А.Лавренёв, Б.Л.Горбатов, Н.Ф.Погодин, А.И.Гельман, Ф.Вольф, Н.Хикмәт, Э. де Филиппо, Э.Раннет, М.Байҗиев, М.Кәрим пьесаларының тәрҗемәләре, Ч.Айтматов прозасы инсценировкалары кертелә.

*Әд.:* Татар театры (1906–1926). К., 2003; Илялеова И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала: Биогр. белешмәлек. К., 2005; Крути И. Русский театр в Казани. М., 1958; Илялова И. Театр имени Камала. К., 1986; Илялова И., Ингвар И. Русский театр в Казани. К., 1991; Илялова И. Репертуар Татарского государственного академического театра им. Г.Камала (1906–2006). К., 2006.

*Ю.А.Благов, И.И.Илялова.*

**РЕПРЕ́ССИЯЛӘР**, к. *Татарстанда 1918–54 еллар репрессияләре.*

**РЕПРЕССИЯЛӘНҮЧЕЛӘРНЕ́ АКЛА́У**, мәхкәмә аша яки адм. тәртиптә, сәяси репрессия корбаннарының хокукларын торгызу. Совет хакимияте елларында миллионнарча кеше сәяси һәм дини инанулары өчен, социаль яки милли чыгышына карап *репрессияләргә* дучар ителә. Р.а. процессы И.В.Сталинның вафатыннан соң башлана. Мәхкәмәдән тыш орган — СССР эчке эшләр министры каршындагы Махсус киңәшмә бетерелә; СССР Югары суды, СССР Ген. прокуроры протесты буенча, элекке ОГПУ коллегияләре, НКВД-УНКВД «өчлек»ләре», НКВД-МГБ-СССР Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Махсус киңәшмә карарларын кабат карау хокукы ала; контррев. җинаятьләрдә гаепләнеп хөкем ителгәннәрнең җинаять эшләрен кабат карау өчен комиссияләр төзелә һ.б. чаралар күрелә. КПССның 20 нче съездында (1956 елның феврале) КПСС ҮКның 1 нче секретаре Н.С.Хрущев 1930 еллар — 1950 еллар башындагы массакүләм репрессияләр турында доклад ясаганнан соң, Р.а. киң колач ала. Хрущёв «җепшеклеге» чорында — 1950 еллар уртасында СССРда 800 мең кеше аклана. 1960 елларда Р.а. процессы туктала, 1980 еллар ахырында, «үзгәртеп кору» чорында, кабат кузгатыла. 1987 дә 1930–40 лар һәм 1950 ләр башы репрессияләре б-н бәйле материалларны өстәмә тикшерү өчен КПСС ҮК Политбюросы комиссиясе төзелә. 1988 дә СССРның прокуратура һәм дәүләт куркынычсызлыгы органнарына, гражданнардан гариза яки шикаять булу-булмауга карамастан, 1930 еллар — 1950 еллар башында репрессияләнгәннәрнең эшләрен кабат карау йөкләтелә. СССР Югары Советы Президиумының «1930–40 еллар һәм 1950 еллар башы репрессияләре корбаннарына карата гаделлекне торгызу буенча өстәмә чаралар күрү турында» («О дополнительных мерах по восстановлению справедливости в отношении жертв репрессий, имевших место в период 30–40-х и начала 50-х годов», 1989) Указында Сталин чорындагы мәхкәмәдән тыш үткәрелгән массакүләм репрессияләр гаепләнә; НКВД-УНКВД «өчлек»ләре, ОГПУ коллегияләре һәм НКВД-МГБ-СССР Эчке эшләр министрлыгы Махсус киңәшмәләренең мәхкәмәдән тыш кабул иткән карарлары, конституциягә каршы килүләре танылып, гамәлдән чыгарыла; әлеге органнар карарлары буенча репрессияләнгән гражданнар акланган дип санала. Указны тормышка ашыру барышында 1 млн. 730 мең кеше аклана. СССР Президенты М.С.Горбачёвның «1920–50 еллар сәяси репрессияләренең барлык корбаннары хокукларын торгызу турында» («О восстановлении прав всех жертв политических репрессий 20–50-х годов», 1990) Указында крәстиян хуҗалыкларын көчләп күмәкләштерү чорында җәберләнгәннәрдән «гаделсезлек табы» алынмавы билгеләп үтелә; рухани катлау вәкилләрен һәм дини мотивлар буенча эзәрлекләнгәннәрне аклау зарурлыгы әйтелә. 1920–50 еллар репрессияләре: күмәкләштерү чорында крәстияннәргә мөнәсәбәт, ш.у. кешеләрне сәяси, социаль, милли, дини һ.б. мотивлар буенча эзәрлекләү законсыз дип

таныла; репрессияләнгән гражданнарның хокуклары тулысынча торгызыла. РСФСРда, «Сәяси репрессия корбаннарын аклау турында» («О реабилитации жертв политических репрессий») 1991 ел 18 октябрь Законы нигезендә, «дәүләткә каршы яки башка төр җинаятьләре өчен» сәяси мотив б-н хөкем ителгәннәр, ВЧК, ГПУ-ОГПУ, НКВД-УНКВД, МГБ, Эчке эшләр министрлыгы органнары, прокуратура һәм аның коллегияләре, комиссияләре, «махсус киңәшмәләр», «икелек»ләр, «өчлек»ләр һәм мәхкәмә функцияләрен үтәүче башка органнар тарафыннан җинаять җаваплылыгына тартылганнар; адм. тәртиптә сөргенгә җибәрелгән, яшәгән урыннан куылуга, махсус урында яшәүгә дучар ителгәннәр аклану мөмкинлеге ала; РСФСР терр-ясендә 1917 нең 25 октябреннән (7 ноябрь) соң сәяси репрессиягә дучар булганнар ш.у. аклана. Акланганнарның социаль-сәяси һәм гражданлык хокуклары торгызыла, хәрби һәм махсус дәрәҗәләре, хөкүмәт бүләкләре кайтарыла, аларга ташламалар бирелә, компенсацияләр түләнә. Болардан тыш, 1990 елларда Россия гражданнарына — элекке совет хәрби тоткыннарына, ш.у. Бөек Ватан сугышы елларында һәм сугыштан соңгы чорда репатриациягә дучар ителгән хәрби булмаган затларга законлы хокуклары кайтарыла; репрессия эзәрлекләвен һәм җәберен кичергән руханилар һәм дин тотучыларны аклау буенча чаралар күрелә. Р.а. эчке эшләр органнары һәм прокуратура аша да алып барыла. Акланган сәяси репрессия корбаннарының хокукларын торгызу буенча, ш.и. Татарстанда да, комиссияләр эшли. РФ башкарма хакимияте федераль органнарының Р.а. турындагы Федераль законны тормышка ашыру буенча алып барган эшчәнлеген РФ Президенты каршындагы комиссия координацияли.

1989–98 дә ТР Прокуратурасы тарафыннан 11636 җинаять эше кабат карала, нәтиҗәдә 20643 кеше аклана. ТР Эчке эшләр министрлыгында РФдә һәм БДБ илләрендә яшәүчеләрдән 48700 дән артык мөрәҗәгать кабул ителеп карала, алар буенча 64500 кеше аклана. ТРда «Сәяси репрессия корбаннарының хәтер китабы» (2000–10, т. 1–24) нәшер ителә. Казанда сәяси репрессия корбаннарына мемориал һәм һәйкәл ачыла. 2006 да РФ прокуратурасы органнары тарафыннан сәяси репрессия корбаннарына караган җинаять эшләрен тикшерү тәгәлләнә; 775 меңнән артык кеше аклана. 30 октябрь РФдә Сәяси репрессия корбаннарын искә алу көне буларак билгеләп үтелә. Ш.у.к. *Татарстанда 1918–54 еллар репрессияләре.*

*Әд.:* Мостафин Р.Ә. Репрессияләнгән татар әдипләре. К., 2009; Султанбеков Б.Ф., Хакимзянов Р.Г. Политические репрессии в Татарстане: Законы, исполнители, реабилитация жертв. К., 2002; Мустафин Р.А. Поимённо вспомним всех = Һәрберсен исемләп искә алыйк = Remember their names. К., 2014.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**РЕПРОДУ́КЦИЯЛӘҮ ХУҖАЛЫГЫ́**, к. *Нәселле терлек үрчетү.*

**РЕПТИ́ЛИЯЛӘР**, к. *Сөйрәлүчеләр.*

**РЕПЬЁВКА** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 28 *км* төньяк-көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш. 2010 елда 8 кеше (руслар, чуашлар) яши. 19 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Морат Пүчинкәсе исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 76 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ульянково волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1859 да — 46, 1897 дә — 96, 1908 дә — 120, 1920 дә — 74, 1926 да — 87, 1938 дә — 245, 1949 да — 190, 1958 дә — 239, 1970 тә — 59, 1979 да — 40, 1989 да — 22, 2002 дә — 8 кеше.

**РЕСПУ́БЛИКА БАЛАЛА́Р КИТАПХАНӘСЕ́**, Казанда 1919 елда Казан ун-ты профессоры Н.К.Нелидовның кызы Екатерина Николаевна Нелидова (1864–1930) башлангычы б-н ачыла. Беренче атамасы — Беренче балалар китапханәсе, 1919 ның ахырыннан А.С.Пушкин исем. Үзәк балалар китапханәсе, 1954 тән Татарстан респ-ка балалар китапханәсе дип йөртелә башлый. 1919–32 һәм 1954 тән балалар арасында китапханә эшчәнлеген оештыру буенча респ-ка методик үзәге. 1922 дән — Мәскәү мәктәптән тыш эш методлары ин-ты, 1950 дән Н.К.Крупская исем. Ленинград китапханә ин-ты студентларының практика үтү җирлеге булып хезмәт итә. Хәзерге вакытта ТР Мәдәният министрлыгына караган 90 балалар китапханәсе һәм 1309 авыл китапханәсенең методик үзәге. 1920 еллардан башлап балалар йортлары, мәктәп, уч-ще, пионер лагерьлары каршында күчмә күргәзмәләр оештырыла. 1920–30 да сәяси, әдәби-иҗади, әдәби, яшь хикәячеләр, китап төпләүчеләр, яшь туристлар, китапханә түгәрәкләре эшли. Әлеге елларда булачак язучы һәм шагыйрьләрдән Җ.Тәрҗеман, Г.Галиуллин, М.Галиевлар китапханәнең даими укучылары була. Китапханә эшчәнлегендә танылган язучы һәм шагыйрьләр Әминә Бикчәнтәева, Сибгат Хәким, Абдулла Алиш, Фатих Хөсни, Идрис Туктаров, Шамил Гәрәй актив катнашалар. 1932 дән китапханәнең татар бүлеге эшли башлый.

Р.б.к.нең 9 китапханә пункты бар (мәктәп, ял итү лагерьларында һ.б.). Андагы әдәбият 15 яшькәчә балаларга исәпләнә: буяу китаплары, әкиятләр, тылсымлы әдәбият, фантастика, сәяхәтләр, туган якны өйрәнү һәм милли әдәбият, сәнгать, музыка турында китаплар, ноталар һ.б. 247 вакытлы матбугат басмасы яздырыла. Китапханә фонды: 1919 да — 5000 данә, 1930 да — 9280 данә (китап берү — 79921 данә), 1954 тә — 32089 данә (китап бирү — 138219), 1970 тә — 126117 данә (китап бирү — 165805), 2014 нең 1 гыйнварына — 132300 данә, ш.и. татар телендә — 12685, китап бирү — 300000 данә тәшкил итә. Китапханәнең уку залы 50 кешегә исәпләнгән. 1960 тан 1981 гә кадәр китапханәара абонемент яшәп килә. Укучылар саны 1930 да — 2457, 1954 тә — 6265, 1970 тә — 9632 кеше, 2014 нең гыйнварына — 16116 кешегә җитә. Шуларның 15043 е балалар һәм 1073 е балалар укуын оештыручылар (укытучылар, ата-аналар, балалар бакчалары һәм интернат тәрбиячеләре). Электрон каталоглар (яңа әдәбият һәм тематик — «Балачак дөньясы»), картотекалар (систематик һәм төбәкне өйрәнү) бар.

2014 тә китапханә штатында 58 кеше эшли. 9 бүлек: 1) фәнни-методик; 2) белешмә-библиографик һәм мәгълүмат эше, милли һәм төбәкне өйрәнү библиографиясе; 3) комплектлаштыру, фонд һәм каталогларны эшкәртү һәм исәпләү; 4) саклау, балалар укуын оештыручыларга һәм стационардан тыш хезмәт күрсәтү; 5) сәнгать һәм кинофотодокументлар; 6) китапханә һәм мәгълүмат системаларын автоматлаштыру; 7) массакүләм эш; 8) төбәкне өйрәнү һәм милли әдәбият; 9) 1–9 сыйныф укучыларына хезмәт күрсәтү бүлекләре эшләп килә.

Китапханәнең җитәкчеләре — Е.Н.Нелидова (1920 еллар), Н.Г.Кустовская (1930 еллар), М.К.Шнейдер (1940 еллар), М.Г.Галиева, А.Н.Глаголева (1950 еллар), В.Е.Мазур (1960 еллар), С.С.Юлмәтова (1976–96), Р.Т.Сираева (1996 дан). Китапханәдә А.Л.Дьякова, Р.Н.Шәйхиева, Л.М.Комарова, Е.Г.Шемелова, Л.Г.Белоусова 30–40 еллап хезмәт итәләр.

Китапханәдә «Яшь укучы тавышы» («Голос юного читателя», 1923) стена г-тасы, «Балаларның нәни дөньясы» («Детский мирок»; 1924 тән — «Безнең хезмәт» — «Наш труд») кулъязма ж-лы, «Без нәрсә һәм ничек укыйбыз» («Что и как мы читаем», 1944) бюллетене, ш.у. «Балалар китапханәсе — Детская библиотека» ж-лы (2002–12) чыга.

*Р.Т.Сираева, Е.Г.Шемелова.*

**РЕСПУ́БЛИКА БАЛАЛА́Р КЛИ́НИК ХАСТАХАНӘСЕ́**, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында, киң профильле респ-ка балалар дәвалау-диагноз кую комплексы; Казан мед. ун-ты һәм Казан мед. академиясе кафедраларының клиник базасы. ТР, Идел һәм Урал буе балаларына стационар һәм хастаханәдән тыш мед. ярдәме күрсәтә.

1970 еллар уртасына кадәр респ-када бердәм педиатрия хезмәте булмый; балалар бүлеге өчен Респ-ка клиник хастаханәсендә 70 ятак-урын бүленә, алар, авыру төренә карап, өлкәннәр дәвалана торган бүлекләрдә урнаштырыла. Р.б.к.х. 1977 елда Казан шәһәре читендәге яшел массивта ачыла (3 дәвалау корпусы, 2 ярдәмче корпус). 1994 тә кардиохирургия, нейрохирургия, офтальмология һ.б. хезмәтләр күрсәтелүче яңа дәвалау корпусы сафка баса. Р.б.к.х. стационарда — 104, поликлиникада 26 белгечлек буенча хезмәт күрсәтә. Компьютер һәм магнит-резонанс томографиясе, ангиография, гемодиализ, эндоскопик хирургия һ.б. заманча ысуллар кулланыла. Балалар комплексы структурасын консультация поликлиникасы һәм 11 соматик, 12 педиатрия, 10 хирургия, 4 диагноз



Республика балалар клиник хастаханәсе. Дәвалау корпуслары. Казан.

кую бүлекләрен берләштергән хастаханә, 4 реанимация-анестезиология хезмәте һәм параклиник хезмәт тәшкил итә. Р.б.к.х. базасында Респ-ка фәнни-гамәли үзәкләре — кардиология, пульмонология, уронефрология, иммунология, онкогематология; Республикаара үзәкләр — балалар хирургиясе һәм урология, ишетү сәләтен торгызу, сурдология, экстракорпораль детоксикация һәм бөер трансплантациясе, күчмә бригадалы реанимация-консультация хезмәте эшли. Үзәкләр Н.П.*Медведев*, М.Р.*Рокицкий*, А.Ә.*Ахунҗанов* тарафыннан оештырыла. 1996 да респ-дагы демографик халәтне, авырулар санын, диспансер күзәтүе һәм иммунопрофилактика торышын, балалар үлеме очракларын анализлау б-н шөгыльләнүче оештыру-икътисад һәм дәвалау-эксперт бүлеге ачыла. Р.б.к.х.ндә 2000 ләп кеше эшли. Бер үк вакытта стационарда — 860, бер ел эчендә 25 мең бала дәвалана, 8 меңләп операция ясала; амбулаториядә көн саен 500 авыру кабул ителә. Баш табиб — Р.Ф.Шәвәлиев (2010 нан).

*Е.В.Карпухин.*

**РЕСПУ́БЛИКА КЛИ́НИК ВЕРТЕБРОНЕВРОЛО́ГИЯ ҮЗӘГЕ́**, к. *Вертеброневрология*.

**РЕСПУ́БЛИКА КЛИ́НИК ХАСТАХАНӘСЕ́** (РКБ), ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында, киң профильле мед. учреждениесе; респ-ка районнары һәм шәһәрләренең мед. белгечләренә оештыру-методик ярдәм күрсәтү үзәге. 1953 елның 25 июнендә Казанда ачыла. Хастаханә «иске клиника» биналарында урнашкан терапия (75 ятак-урын), хирургия (85), неврология (65) бүлекләрен; «яңа клиникалар» биналарындагы хирургия (75), күз авырулары (100), бала тудыру (45), гинекология (50), тире-венерология (60), балалар авырулары (80) бүлекләрен; отоларингология (50) һәм психиатрия бүлекләрен берләштерә. Баштагы чорда хастаханә стационар ярдәм күрсәтә. 1955 нең 21 сентябреннән поликлиника бүлеге эшли башлый.

Р.к.х. составыннан, мөстәкыйль махсус мед. учреждениесе буларак, тире-венерология (1957) һәм психиатрия (1960) бүлекләре аерылып чыга. 1977 дә балалар авырулары бүлеге (соңрак балалар соматик авырулары һәм туберкулёз-менингит бүлекләре) яңа ачылган Респ-ка балалар клиник хастаханәсенә күчерелә. 1969 да РКБның стационарлы төп корпусын, операция блогын, поликлиника, патологик анатомия һәм хуҗалык корпусларын (1978), азык-төлек блогын (1983), адм. корпусны (1983), кан тапшыру станциясенең яңа бинасын (1990) берләштергән яңа комплексына нигез салына. 2001 дә акушерлык корпусы (100 ятак-урын) сафка баса. 2009 да Р.к.х.нә Татарстан «Травматология һәм ортопедия» фәнни-тикшеренү үзәге кушылып, Респ-ка травмаларны дәвалау фәнни-гамәли үзәге булдырыла.

2014 елда Р.к.х. составында 35 махсус бүлекне берләштергән 1309 ятак-урынлы стационар; көнгә 955 кеше кабул итеп, 41 төр белгечлек буенча консультация бирүче поликлиника (стационар һәм поликлиника пациентларының 65% тан артыгы ТРда яшәүчеләр); диагноз кую һәм ярдәмче бүлекчәләр; операция блогы; дәвалау-эксперт бүлекчәсе б-н оештыру-методик ярдәм бүлеге; ашыгыч һәм планлы-консультатив ярдәм бүлеге (сан. авиациясе) һ.б. эшли. Р.к.х. Казан. мед. ун-тының — 13, Казан мед. академиясенең 3 кафедрасы өчен база булып тора. Консультатив поликлиника составында респ-ка ревматология үзәге, яшүсмерләр кабинеты, гаиләне планлаштыру үзәге хезмәт күрсәтә, биредә ш.у. мед.-генетик консультация бирелә. Хастаханәдә ел саен 18 меңнән артык операция ясала, планлы рәвештә респ-ка районнарындагы мед. учреждениеләренә барып ярдәм күрсәтү (елга 700 дән артык) оештырыла.

Р.к.х.ндә 2660 кеше: 500 табиб (ш.и. 5 мед. фән. д-ры, 77 мед. фән. канд-ты), 10 провизор,



Республика клиник хастаханәсе. Төп корпус. Казан.

1023 урта мед. хезмәткәре, 517 кече мед. персоналы, 600 дән артык адм.-хуҗалык хезмәткәре эшли. 4 кеше — РФнең, 38 кеше — ТАССР һәм ТРның атказ. табибе, 5 урта мед. хезмәткәре — ТРның атказ. сәламәтлек саклау хезмәткәре.

Баш табибләр: М.И.Грачёв (1953–54), Ш.В.Бикчурин (1955–61), К.Л.Свечников (1961–68), М.В.Буйлин (1968–86), С.В.Абуладзе (1986–95), Р.Г.Фатихов (1995–2002), М.В.Кормачёв (2002–2010), Р.Ф.Гайфуллин (2010 нан).

*Ф.Ф.Нуриева.*

**РЕСПУ́БЛИКА КЛИ́НИК ХАСТАХАНӘСЕ́ № 2** (РКБ № 2), ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында, киң профильле дәвалау-профилактика учреждениесе. 1945 елда Казан шәһәренең 3 нче клиник хастаханәсе базасында стационар (25 ятак-урын) буларак ачыла. 1982 дә 7 катлы корпус салына (ятак-урын саны 300 гә җитә). 1990 да ультратавыш ярдәмендә диагноз кую, магнит-резонанс томографиясе бүлекләре ачыла; 1990 нан поликлиникада беркетелгән контингентка мед. ярдәме һәм респ-каның башка мед. учреждениеләрендә дәваланучы авыруларга консультатив ярдәм күрсәтүче 2 бүлек эшли; 1994 тә компьютер-рентген томографиясе, ангиография, 1995 тә — эндоскопик хирургия бүлекләре булдырыла.

Хастаханә составында көнгә 20 белгечлек буенча 500 кеше кабул итүче поликлиника, 305 ятак-урынлы стационар, операция блогы булган реанимация бүлеге, спелеокамерасы һәм психоэмоциональ халәтне көйләү бүлмәсе булган энә терапиясе кабинеты бар. Хастаханәдә коронография, коронар һәм йокы артерияләре ангиопластикасы, стенирлау, интракоронар тромболизис, баш миендәге кан тамырлары аневризмасы һәм аналык миомасы очракларында аналык артерияләре эмболизациясе эшләнә. 2003 тә компьютер рентген томографы, 2004 тә өч үлчәмле сурәт тудыручы ультратавыш аппараты, 2005 тә хәзерге чор магнит-резонанс томографиясендә гамәлдә булган күпчелек ысулларны куллану мөмкинлегенә ия куәтле магнит-резонанс томографы урнаштырыла. Биредә ш.у. төнге йокыга полисомнографик тикшерү уздырыла.

РКБ № 2 табибләре тарафыннан йөрәк-кан тамырлары авыруларына кичекмәстән диагноз кую һәм дәвалау, көчле миокард инфарктын аз инвазияле технологияләр кулланып дәвалау; баш миенең кан тамырлары җитешсезлеге, таркау склероз һ.б. мускул зәгыйфьлегенә китерүче авыруларга кичекмәстән диагноз кую һәм дәвалау; ашказаны-эчәк тракты авыруларына, ш.и. ашказаны һәм эчәклектәге шешләргә кичекмәстән диагноз кую һәм дәвалау; аналыктагы яман булмаган шешләрне дәвалаганда аз инвазияле технологияләр куллану һ.б. темаларга фәнни тикшеренүләр алып барыла. Хастаханә Казан мед. академиясенең 5 кафедрасы өчен база булып тора.

Хастаханәдә ел саен 300 мең пациент дәвалана. 2016 елга биредә 1850 дән артык хезмәткәр исәпләнә (4 мед. фән. д-ры, 15 мед. фән. канд-ты), 893 урта һәм кече мед. персоналы

эшли. 19 кеше — РФнең һәм ТРның атказ. табибе һәм 1 кеше ТРның атказ. икътисадчысы.

2016 дан — Казан ун-ты клиникасы составында.

Баш табибләр: Н.И.Чугунов (1959–86), И.В.Клюшкин (1986–94), Р.Ж.Абашев (1995–2011), А.Р.Абашев (2012 дән).

*Р.Ж.Абашев, Ф.Ф.Нуриева.*

**РЕСПУ́БЛИКА КЛИ́НИК ХАСТАХАНӘСЕ́ № 3**, к. *Казан медицина академиясе клиникалары.*

**РЕСПУ́БЛИКА КЛИ́НИК ХАСТАХАНӘСЕ́ № 4**, к. *Травматология һәм ортопедия үзәге.*

**РЕСПУ́БЛИКА КҮЗ АВЫРУЛАРЫ́ ХАСТАХАНӘСЕ́**, 1922 елда Казанда Трахоматоз ин-ты буларак ачыла (1933 тән Е.А.Адамюк исем.), 1956 дан ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка трахоматоз диспансеры, 1964 тән — хәзерге исемдә. 1922 дә ин-т составына оештыру-методик үзәк, эксперт-биол. һәм патологик анатомия лаб-яләре керә. Ин-т Татарстан, Мари, Чуаш, Мордва респ-каларында трахомага каршы көрәш алып бара. 1960 еллар уртасына ТАССРда трахома авыруын бетерүгә ирешелә. 1970 тә хастаханәнең 50 ятак-урынлы хирургия корпусы төзелә, 2007 дә микрохирургия корпусы сафка баса.

Р.к.а.х. респ-када офтальмология хезмәте күрсәтүче төп учреждение булып тора. Ул поликлиника, ашыгыч ярдәм бүлекләрен, 3 микрохирургия бүлеген; ультратавыш ярдәмендә диагноз кую, электр тогы һәм лазер нурлары ярдәмендә дәвалау, энә терапиясе, лазер офтальмохирургиясе, күз протезы, глаукома, комплексы амбулатор дәвалау кабинетларын берләштерә. Хастаханәдә мед. фән. кандидатлары, югары һәм 1 нче категорияле табибләр, 50 дән артык урта мед. персоналы эшли. Р.к.а.х. җитәкчелегендә глаукома б-н авыручыларны ачыклау буенча респ-ка программасы тормышка ашырыла, күз авыруларын кисәтү чаралары күрелә, тәүлек әйләнәсе эшләүче ашыгыч офтальмологик ярдәм хезмәте (елга 18 мең чакыру, барлык төр күз авыруларын дәвалаучы 250 ятак-урынлы стационар бар. Ел саен 25 меңләп кешегә консультация бирелә, 10 меңнән артык операция (ш.и. интраокуляр линзалар имплантациясе б-н катаракта экстракциясе), лазер операцияләре ясала.

1933–37 елларда «Вопросы трахомы» журналы нәшер ителә. Баш табибләр: Ю.П.Прищенко (1958–76), Ю.А.Расчёсков (1976–2002), А.Н.Әмиров (2002 дән).

*Әд.:* Здравоохранению Республики Татарстан 75 лет. К., 1996.

*А.Н.Әмиров, Р.Г.Исхакова.*

**РЕСПУ́БЛИКА КҮЧМӘ́ ТЕА́ТРЫ**, к. *Татар драма һәм комедия театры*, Тинчурин исемендә.

**РЕСПУ́БЛИКА МАХСУ́С СУКЫРЛА́Р КИТАПХАНӘСЕ́**. Казанда 1933 елда 15 нче номерлы шәһәр китапханәсе җирлегендә ачыла, 1935 тән — Казан шәһәре махсус сукырлар китапханәсе дип, 1967 дән хәзерге исеме б-н атап йөртелә башлый. Китапханәдә 1953 тән авыл җирлегендә яшәүче сукырларга стационардан тыш хезмәт күрсәтүче бүлек ачыла (читтән торып һәм өй абонементы). 1961 дән Р.м.с.к. татар телендә «сөйләүче» китаплар (магнитофон тасмасындагы язмалар) чыгара башлый. Бу исә Татарстан районнарында, ш.у. Россиянең башка төбәкләрендә яшәүче күрмәүче укучыларга да аның фондыннан файдаланырга мөмкинлек бирә. Китапханә фондлар һәм каталогларны оештыруның яңа төрләрен эшләп чыгаруда катнаша. Китапханәнең 1936–68 дәге директоры А.Д.Горных мондый тип китапханәләр өчен стандартка әверелгән аңлатмалы карточкалар уйлап чыгара. 1975 тә сукырлар өчен оештырылган китапханәләрне үзәкләштерү башлана: Бөгелмә, Алабуга, Чистай шәһәрләрендә китапханәләр Р.м.с.к.нең ф-лына әверелә, ә ул үзе күрмәүче укучыларны реабилитацияләү буенча респ-ка оештыру-методик һәм библиографик үзәге булып тора. 1990 елларда белгечләр, студентлар, укучылар һ.б. өчен компьютерлаштырылган үзәк ачыла. Китапханә Татарстан инвалидларына хезмәт күрсәтүгә яраклаштырылган үзәк булып тора. Аның иң мөһим юнәлеше — күрмәүче инвалид балаларны мәгълүмат б-н тәэмин итү.

2014 елга Р.м.с.к. фонды 350941 саклау берәмлеген тәшкил итә, анда ш.и. яссы-басма шрифтта — 45216 (шуның 750 данәсе — журналлар); рельефлы-нокталы шрифтта — 86526 (журналлар — 200 данә); магнитофон язмасында 140 лап китап һәм 1000 журнал; электрон басмалар 28845, 2 меңнән артык грампластинка, 40 тан артык тифлографика саклана. Тифлология буенча уникаль фондта танылган сукыр кешеләрнең тормышы һәм эшчәнлеге турындагы язмалар, ш.у. 46 мең саклау берәмлеге чамасы татар телендәге әдәбият саклана.

Белешмә фонд эшләп килә. Алфавитлы систематик (яссы-басма шрифт, рельефлы-нокталы шрифт), «сөйләүче китап» грампластинка каталоглары; газета-журнал язмалары, китап исемнәре буенча картотекалар (Брайль һәм яссы-басма шрифт) бар.

Китапханә сукырларга, начар күрүчеләргә, аларның гаиләләренә, сукырларга хезмәт күрсәтүче кешеләргә, башка төр инвалидларга һәм тифлология мәсьәләләре б-н шөгыльләнүче абонентларга хезмәт күрсәтә.

Китапханә структурасында абонемент, өй абонементы, уку залы, стационардан тыш бүлек (читтән торып китап алу), китапханәара абонемент, тавыш яздыру, китап фондын туплау һәм эшкәртү, методик оештыру һәм библиография эшчәнлеге бүлеге, китапханә эшләрен автоматлаштыру бүлеге, махсус технология һәм нәшрият эшчәнлеге бүлекләре эшли.

Респ-ка махсус сукырлар китапханәсенең 6 ф-лы бар, алар Казан, Бөгелмә, Алабуга, Чистай, Әлмәт, Чаллы шәһәрләрендә. Китапханә ел саен 4 меңләп укучыга хезмәт күрсәтә.

*Н.И.Сәфәргалиев.*

**РЕСПУ́БЛИКА МЕДИЦИ́НА ДИА́ГНОЗ КУЮ́ ҮЗӘГЕ́** (РКБ-2), к. *Республика клиник хастаханәсе № 2.*

**РЕСПУ́БЛИКА МЕДИЦИ́НА КИТАПХАНӘ́-МӘГЪЛҮМА́Т ҮЗӘГЕ́**, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында, к. *Китапханә-мәгълүмат үзәге.*

**РЕСПУ́БЛИКА МЕДИЦИ́НА ПРОФИЛА́КТИКАСЫ ҮЗӘГЕ́**, халыкның сәламәтлеген ныгытуга юнәлдерелгән чаралар системасын тормышка ашыру хезмәте һәм учреждениесе. 1948 елда Респ-ка дәвалау-физкультура үзәге буларак оештырыла, 1951 дә Респ-ка дәвалау-физкультура диспансеры дип үзгәртелә, 1991 дә Санитария белеме бирү йорты б-н берләштерелеп, хәзерге исемендә. Әлмәт, Чаллы, Түбән Кама, Яшел Үзән, Лениногорск шәһәрләрендә аерым шәһәр мед. профилактика үзәкләре бар. Респ-ка үзәгендә респ-ка җыелма командаларыннан 10400 ләп спортчы һәм балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләрендә шөгыльләнүчеләр исәптә тора. Р.м.п.ү. алдына куелган бурычлар һәм максатлар: халыкта сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру, имгәнүләрне, төрле авырулар таралу һәм аларның катлаулану очракларын, респ-каның проф. спортчылары сәламәтлеген профилактик контрольдә тоту, нормадан тайпылыш очракларын анализлау, сәламәтлекне кайтару чараларын күрү. Үзәктә ел саен 200 ләп белгеч: дәвалау физкультурасы, спорт медицинасы табибләре, реабилитологлар, массажистлар, дәвалау физкультурасы инструкторлары стажировка уза; төрле семинарлар (ш.и. дәвалау-профилактика учреждениеләре табибләре өчен) үткәрелә, даими курслар эшли; мөстәкыйль шөгыльләнү өчен дәвалау гимнастикасы методикасы булдырылган. Р.м.п.ү. үзенең эшен Казан мед. академиясе, Казан мед. ун-ты, Казан мед. көллияте б-н берлектә алып бара. Үзәктә эшләүче хезмәткәрләр дәвалау-профилактика учреждениеләре өчен мәгълүмати материаллар әзерлиләр, мед. һәм гигиенага кагылышлы белемнәрне, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалыйлар; төрле акцияләр, күргәзмә, конкурс, конференцияләр уздыралар; методик әдәбият нәшер итәләр, өйрәтмә фильмнар төшерәләр һ.б. 2011 дә Р.м.п.ү. системасын 5 шәһәр һәм 1 респ-ка үзәге, 97 мед. профилактикасы кабинеты тәшкил итә. Үзәктә 100 дән артык хезмәткәр (табибләр, урта мед. персоналы һ.б.) эшли, алар 1 меңнән артык кешегә хезмәт күрсәтә. ТРда мед. профилактикасы өлкәсендә аеруча зур хезмәт куйган табибләр: В.М.Протасов, Т.К.Шулешкина, Н.Г.Низаметдинова, Ф.Х.Фәтхуллин, Э.И.Әүхәдиев, В.Х.Даловский, Т.В.Филиппова, Р.А.Нурмөхәммәтова һ.б.

Үзәкнең җитәкчеләре: Т.К.Шулешкина (1948–79), Н.Г.Низаметдинова (1979–93), Р.В.Таҗиев (1993–2010), Р.С.Садыйкова (2010 нан).

*Р.В.Таҗиев, Р.Р.Камалова.*

**РЕСПУ́БЛИКА НАРКОЛО́ГИЯ ДИСПАНСЕРЫ́**, к. *Наркомания, Диспансерлар.*

**РЕСПУ́БЛИКА ОНКОЛО́ГИЯ КЛИ́НИК ДИСПАНСЕРЫ́**, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында, респ-када онкология хезмәтен координацияләүче баш учреждение, ТР һәм Идел буе федераль округы терр-ясендә яман шеш авыруларын кисәтү, диагноз кую һәм дәвалау

буенча методик ярдәм күрсәтә һәм оештыру эшләренә җитәкчелек итә. 1946 елда оештырыла. Исеме бернічә тапкыр үзгәртелә: Респ-ка онкология диспансеры (1946–92), ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Онкология клиник үзәге (1992–2000), 2000 нән хәзерге исемдә.

Р.о.к.д. составына Казан һәм Чаллы шәһәре диспансерлары, Яшел Үзән һәм Түбән Кама үзәк р-н хастаханәләрендәге онкология бүлекләре, Казандагы онкология кабинетлары керә. 1972 гә кадәр 20 ятак-урынлы стационары һәм поликлиникада кабул итү кабинеты булган диспансер Казан шәһәренең 5 нче хастаханәсе базасында эшли. 1972 дән 3 катлы аерым дәвалау корпусында урнаша.

Диспансер структурасын поликлиника, маммология үзәге, 7 бүлек (дәвалау, диагностика, мед.-радиацион физика һәм техника, оештыру-методика, фәнни, информатика, капиталь төзелеш), аптека тәшкил итә.

Дәвалау бүлегендә (13 подразделение һәм операция блогы) авыруларга беренчел кабул итү һәм консультация уздырыла, диагноз куела, операция алды тикшерүе һәм махсус дәвалауга әзерлек үткәрелә.

2 торакаль бүлектә шешләре төрле тупланышта (үпкәдә, трахеяларда, күкрәк куышлыгының алгы өлешендә, плеврада, күкрәк читлегенең йомшак тукымаларында) булган авырулар дәвалана; үпкәгә һәм күкрәк куышлыгына, үңәчкә, корсак куышлыгы һәм кече оча сөяге әгъзаларына эндохирургик операцияләр ясала; үңәчтә, ашказанының кардиаль бүлегендә, күкрәк куышлыгының арткы өлешендә шеш һәм яман шеш очракларында хирургик дәвалау уздырыла; үңәч рагын комбинацияле дәвалау, пластик һәм реконструктив хирургия ысуллары кулланыла. Бүлекләр үңәч авыруларына, плевритларга, күкрәк бизе рагына диагноз кую һәм дәвалау буенча заманча ысулларга һәм аппаратурага таянып эшли.

Абдоминаль хирургия бүлегендә ашказаны, панкреато-дуоденаль һәм гепатобилиар зоналар, юан һәм туры эчәк, сидек куыгы һәм гениталийлар рагын, йомшак тукымалардагы шешләрне хирургик һәм комбинацияле дәвалау уздырыла (туры эчәк, сидек куыгы, аналык һәм аналык муентыгы рагының урында таралу очрагында, сидек куыгы һәм туры эчәк пластикасы б-н бергә, оча сөяге әгъзалары эвисцерациясе ясала).

Маммология бүлегендә күкрәк бизендә шеш булган авыруларга, регионар лимфа төеннәренә үтеп керүнең оригиналь ысулларын кулланып, хирургик һәм комбинацияле дәвалау уздырыла; үзәк һәм медиаль тупланышлы күкрәк бизе рагы очрагында эндохирургик операцияләр ясала; эндохирургик овариэктомия, радикаль резекция һәм мастэктомияләрдән соң күкрәк бизе пластикасы, ш.у. күкрәк бизенә төрле төр эстетик операцияләр ясала.

Онкоурология бүлегендә сидек һәм җенес органнарында шеш һәм яман шеш булган авыруларга хирургик һәм комбинацияле дәвалау уздырыла, сидек куыгы һәм мәни бизендәге (простата) шешләргә трансуретраль операцияләр ясала.

Онкогинекология бүлегендә гениталийлардагы шешләргә диагноз куела һәм хирургик дәвалау уздырыла; яман шеш очракларында комбинацияле һәм комплекслы дәвалау алып барыла; аналык һәм күкәйлекләрнең киңәйтелгән экстирпациясе очрагында корсак ярысы дренажы ясала; 40 яшьтән яшьрәк хатын-кызларның аналык муентыгы рагын комбинацияле дәвалаганда күкәйлекләр транспозициясе үткәрелә.

Диагностика һәм хирургия бүлегендә эндокрин системасында патология булган авырулар дәвалана, комбинацияле ысуллар б-н дәвалау бүлегендә авыруларны берьюлы химик ысуллар һәм нурлар ярдәмендә дәвалыйлар.



Республика онкология клиник диспансеры.
Төп корпус.

Радиосоматика бүлегендә барлык төр тупланыштагы яман шешле авырулар дәвалана; амбулатория шартларында нурлар ярдәмендә дәвалау ысуллары кулланыла.

Радиогинекология бүлегендә аналыкка һәм аналык муентыгына, күкәйлекләргә һәм вульвага дистанцион юл б-н һәм корсак куышлыгына үтеп нур терапиясе уздырыла; стационардан чыккан авыруларга махсус паллиатив ярдәм күрсәтелә.

Поликлиникада торакаль һәм абдоминаль хирурглар, маммолог, химиотерапевт, оториноларинголог, гинеколог, эндокринолог, уролог, дерматолог, проктолог, стоматолог, терапевт, эндоскопист, нур диагностлары, патоморфолог кабул итә. Җайга салынган тикшерү алгоритмнары 1–3 көн эчендә шешнең морфологик табигатен ачыклап диагноз куярга, стационар яки амбулатор режимда дәвалау төре билгеләргә мөмкинлек бирә.

Поликлиниканың диагностика бүлеге үз эченә клиника-диагностика, патоморфология, цитология, иммунология лаб-яләрен; эндоскопия, калкансыман биз шешләренә диагноз кую һәм дәвалау үзәкләрен, патология-анатомия бүлеген (барлык төр тупланыштагы шешләрне гистохимик күзәтү нәтиҗәсендә 4 мең берәмлек тәшкил итүче уникаль архив тупланган) ала.

Нур ярдәмендә диагноз кую бүлеге рентгенология, ультратавыш, радионуклид һәм радиоиммун лаб-яләрне берләштерә; шешләргә иммуногистохимик юл б-н диагноз кую Респ-ка үзәк лаб-ясе эшли.

Фәнни бүлек диспансер хезмәткәрләренең фәнни тикшеренүләрен координацияли, башка ин-т һәм оешмаларның фәнни хезмәткәрләре б-н уртак тикшеренүләр оештыруда, респ-ка һәм илкүләм фәнни-гамәли конференцияләр, симпозиумнар (5 Бөтенроссия, 10 Респ-ка фәнни-гамәли конференциясе; кешедәге шешләргә иммуногистохимик юл б-н диагноз кую буенча 5 Бөтенроссия укулары; 2000 дә — 5 нче Бөтенроссия онкологлар съезды, 2014 тә — БДБ һәм Евразия илләре онкологлары һәм радиологларының 8 нче съезды) уздыруда катнаша.

Р.о.к.д.ның оештыру-методик бүлеге ТРда онкология хезмәтен камилләштерү юнәлешендә эшли. Популяция һәм госпиталь канцер-регистрлары булдырылу Татарстанда яман шеш проблемалары буенча тулы мәгълүмат алу мөмкинлеге бирә; «Онколог көннәре» оештырыла, респ-каның шәһәр һәм районнарында күкрәк бизе рагын кисәтү һәм кичекмәстән диагноз кую максатыннан «Күкрәктәге ал тасма» («Розовая ленточка на лацкане») акциясе уздырыла.

1972 дә диспансер составына поликлиника, клиник бүлекләр, 2 хирургия, 1 гинекология, 1 радиология, 1 патогистология бүлекләре, 1 торакаль бүлек, рентген кабинеты, клиника-диагностика лаб-ясе кертелә. Диспансер базасында ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының эндоскопия үзәге (1973), үзәк цитология лаб-ясе (1986), Респ-ка калкансыман биз һ.б. эндокрин авыруларга диагноз кую һәм дәвалау үзәге (2001) оештырыла. ТРда беренче тапкыр Респ-ка ракка каршы көрәш программасы (1995) кабул ителә, әлеге программа респ-када онкология хезмәте үсешенә зур өлеш кертә. Р.Ш.Хәсәнов, К.Т.Шакиров, Р.Ф.Ситдыйков, Л.Г.Карпенко, И.А.Гыйләҗетдинов, Р.З.Трегубова, С.И.Моратова, Е.И.Сигалларның «Татарстан Республикасы онкология хезмәте идарәсен оптимальләштерү һәм яман шешле авыруларга ярдәм күрсәтүне яхшырту, социаль-икътисади зыянны киметү максатыннан кулланышка яңа оештыру технологияләре кертү» хезмәте ТР Дәүләт бүләгенә ия була (2003).

Р.о.к.д. каршында онкология авыруларына ярдәм күрсәтү буенча Респ-ка координация советы (1996) оеша, ТРның ракка каршы көрәш фонды, Этика ком-ты (1997) төзелә. Диспансер халыкара, мультиүзәк клиник тикшеренүләрендә катнаша (1997 дән).

1998 дә пансионат, 1999 да дәвалау корпусы, 500 урынлы конференц-зал, азык-төлек блогы, линияле тизләткеч корпусы, 2005 тә үзәк стерильләштерү бүлеге, инфузион һәм башка төр эремәләр җитештерүче линия; 2006 да 12 операция залын эченә алган яңа операция блогы, 18 ятак-урынлы анестезиология һәм реанимация бүлеге, 7 катлы ярдәмче корпус, мед. газлары станциясе, 2013 тә радиология корпусы сафка баса. 2007 дә Р.о.к.д. базасында РМАнең Н.Н.Блохин исем. Россия онкология фәнни үзәге Идел буе ф-лы оештырыла. 2008 дә Казан онкология диспансеры б-н берләштерелә.

2014 тә Р.о.к.д. стационарында (906 ятак-урын) елга 23 мең авыру дәвалана; диспансер штатында 1,2 меңләп хезмәткәр исәп-

ләнә, 145 табибнең 14 е — фән докторлары (ш.и. профессорлар Г.И.Володина, Р.Ш.Хәсәнов, Р.М.Таҗиев, И.Г.Гатауллин, В.Ю.Муравьёв, И.А.Гыйләҗетдинов, С.В.Петров, В.П.Потанин, Е.И.Сигал, И.Р.Әһлиуллин, Р.Х.Галиев), 65 е — мед. фән. кандидатлары; 40 тан артык табиб югары категориягә ия, 10 кеше — ТРның атказ. табибе (В.Ю.Муравьёв, Г.Н.Хәйретдинова, Ф.З.Миндубаева, Л.Г.Карпенко, Р.Ш.Хәсәнов, Е.И.Сигал, И.Р.Әһлиуллин, В.П.Потанин, Р.М.Таҗиев, К.З.Данилов), 2 кеше — РФнең атказ. табибе; 450 шәфкать туташы (ш.и. 11 кеше — ТРның атказ. мед. хезмәткәре).

Директорлар: М.С.Рейтман, П.В.Байков, Р.И.Ахаляев (1946–47); баш табибләр: К.В.Ульянова (1947–58), А.К.Мөхәммәдъярова (1958–85), Р.Ш.Хәсәнов (1985–2015), И.И.Хәйруллин (2015 тән). Ш.у.к. *Онкология.*

*Р.Ш.Хәсәнов, И.А.Гыйләҗетдинов.*

**РЕСПУ́БЛИКА ПСИХИАТРИ́Я КЛИ́НИК ХАСТАХАНӘСЕ́**, В.М.Бехтерев исем., ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында, ТРның психиатрия буенча баш учреждениесе һәм оештыру-методика үзәге; Россиядәге иң өлкән психиатрия учреждениесе. 1869 елның 1 июлендә Казан округ акыл зәгыйфьлеге авырулары йорты (Эчке эшләр министрлыгының Казан округы психиатрия дәваханәсе; 200 ятак-урын, 1917 гә ятак-урыннар 1 меңгә җитә) буларак ачыла. Казан, Түбән Новгород, Вятка, Пенза, Самара, Саратов һәм Сембер губерналарында яшәүчеләргә мед. ярдәме күрсәтә. 1917 дән — Казан психиатрия хастаханәсе; 1934 тән — РСФСР Сәламәтлек саклау халык комис-ты; 1946 дан — СССР Сәламәтлек саклау министрлыгы, 1957 дән — ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында; 2007 дән хәзерге исемдә. Дәваханә алдына башлангыч һәм кискен формадагы психик авыру очракларында авыруларны дәвалау, акылдан язуның клиник яктан шикле очракларын өйрәнү, суд-психиатрия экспертизасы уздыру бурычы куела. Беренче директоры — А.У.Фрезе, бер үк вакытта Казан ун-тының дәваханә базасында эшләүче психиатрия каф. мөдире. Кафедрада аны психиатриянең анатомик-физиол. юнәлеше тарафдары В.М.*Бехтерев* (1885–93) алыштыра. Дәваханәдә Россиядә беренче психофизиол. лаб-я ачыла, анда арка һәм баш миенең үткәрү каналларын, нерв системасының физиол. функцияләрен өйрәнү буенча тикшеренүләр алып барыла. 1885 тә Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан «Казан округ психиатрия дәваханәсендә акыл зәгыйфьлеге авырулары госпиталь клиникасын гамәлгә кую кагыйдәләре» («Правила для устройства госпитальной клиники душевных болезней в Казанской окружной психиатрической лечебнице») раслана. Дәваханәнең фәнни консультанты вазифасын психозлар барлыкка килүдә «тышкы агентлар» һәм инфекцияләр ролен өйрәнүче Н.М.*Попов* (1894–1903 тә Казан ун-тының психиатрия каф. мөдире) башкара; ул психик авырулар клиникасын паталогик-анатомик нигезгә куярга омтыла. Дәваханә һәм кафедра озак еллар буена табиб-психиатрлар әзерләү һәм аларның белемен күтәрү үзәге булып тора; кафедра галимнәре йогышлы психоз, эпилепсия, прогрессив паралич проблемаларын өйрәнү буенча тикшеренүләр уздыралар. 1911 дә дәваханә Дрезден шәһәрендә (Германия) узган халыкара гигиена күргәзмәсендә катнашып, почётлы дипломга лаек була һәм Россиянең иң яхшы психиатрия учреждениесе дип табыла.

1930–40 елларда хастаханәдә дәвалау-диагностика бүлекләре ачыла, клиник лаб-я торгызыла, табиб-дежурантлар эше оештырыла. Т.И.Юдин психиатрия ярдәмен яңа нигезгә куя: тәрбия-күзәтчелек психиатриясе урынына дәвалау психиатриясе гамәлгә керә. С.В.*Курашов* хастаханәнең психиатрия хезмәтен тамырдан үзгәртә: балалар бүлеге, хирургия блогы, рентген кабинеты булдырыла, лаб-яләр эше җайга салына, дәвалау туклануы, хезмәт терапиясе кертелә, авыруларга хастаханәдән тыш ярдәм (поликлиникада тикшерү) күрсәтелә башлый; балалар психопатологиясе һәм инфекцион психоз мәсьәләләре өйрәнелә. Бөек Ватан сугышы елларында хастаханә җирлегендә эвакуацияләнгән фәнни-тикшеренү ин-тлары эшли, хезмәткәрләр арасында профессорлар Р.Я.Голант, Н.Е.Сухарева, О.В.Кербиков, Д.Д.Федотов һәм башка галим-психиатрлар була. М.И.*Грачёв* (1966 дан баш табиб) җитәкчелегендә хастаханәдән тыш психиатрия ярдәме челтәре оештырыла, респ-ка районнарында психиатрия кабинетлары булдырыла. 1973 тә хастаханә җирлегендә Казан ГИДУВының 1937–57 дә эшләгән психиатрия кафедрасы кабат торгызыла (мөдире Д.Г.*Еникиев*). Кафедрада психик авыруларны инсулин комасы һәм психотроп препаратлар б-н дәвалау мәсьәләләре тикшерелә. Неврозлы авырулар һәм авыру чиге халәтендәгеләрне дәвалау бүлеге, хатын-кызлар өчен гериартрия бүлеге ачыла. 1977 дә наркология хезмәте Респ-ка наркология диспансеры буларак аерылып чыга. 1990 елларда ятак-урыннар саны 2,6 меңгә җитә, яңа бүлекләр: фтизиатрия, хирургия, йогышлы авырулар, физиотерапия, соматик бүлек барлыкка килә; авыруларны тикшерү һәм дәвалауның заманча ысуллары һәм 2005 елдан яңа төр хезмәтләр: беренче психотик эпизод, психиатрия эндокринологиясе, «Сердәш» мед.-психол. хезмәтләре гамәлгә кертелә.

Р.п.к.х. Казан мед. академиясе (психотерапия һәм наркология, клиник фармакология һәм фармакотерапия, психиатрия һәм мәхкәмә-психиатрия экспертизасы кафедралары) һәм Казан мед. ун-тының (наркология курсы б-н психиатрия, пед. курсы б-н мед. психологиясе һәм гомуми психология кафедралары) өчен клиник база булып хезмәт итә. Әлмәт, Бөгелмә, Чаллы, Яшел Үзән, Түбән Кама шәһәрләрендә хастаханәнең ф-ллары (психоневрология диспансерлары) бар. Хастаханә 30 дәвалау-психиатрия бүлеген берләштерә; ятак фонды 2,9 мең урын тәшкил итә, көндезге стационар 533 кешегә исәпләнгән. Р.п.к.х.ндә 1500 дән артык кеше: 250 дән артык табиб (ш.и. 2 мед. фән. д-ры, 16 мед. фән канд-ты; 1 — РФнең, 10 ТРның атказ. табибе), 550 — урта, 500 дән артык кече мед. хезмәткәре эшли. 1966 дан «Актуальные вопросы социальной и судебной психиатрии, психотерапии и клинической психологии» җыентыгы нәшер ителә.

Хастаханәнең төрле еллардагы җитәкчеләре: А.У.Фрезе (1869–84), Л.В.Рогозин (1884–88), Я.А.Боткин (1889–92), В.П.Кузнецов (1892–96), В.И.Левчаткин (1897–1914), Т.И.Юдин (1924–1932), Я.М.Жуховицкий (1934–36), С.В.Курашов (1936–41), Г.Г.Каранович (1941–42), Т.Н.Суворова (1942–45, 1956–66), Г.Е.Швидлер (1945–48), А.М.Кравцов (1949–55), М.И.Грачёв (1966–81), Н.С.Макарчиков (1981–99), Ф.Ф.Гатин (1999–2010), Ф.Г.Җиһаншин (2010 нан).

*Әд.:* Республиканская психиатрическая больница // Здравоохранение Республики Татарстан. К., 2000.

*Т.А.Малыгина.*

**«РЕСПУ́БЛИКА СОВЕ́Т ОЕШМАЛАРЫ́ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ́ ТАТА́Р ТЕЛЕ́Н ГАМӘЛГӘ́ КЕРТҮ́ ТУРЫНДА́»**, ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы Декреты. 1921 елның 25 июнендә кабул ителә, 11 пункттан тора. Барлык дәүләт, совет оешмаларында татар телен гамәлгә кертергә күрсәтмә бирелә (җәмәгать, кооператив һәм профсоюз оешмалары өчен искәрмә ясала, күрсәтмәне үтәү аларның үз ирекләренә куела). Декрет нигезендә, ТАССР ҮБК каршында, аерым бүлек хокукында, *Татар телен гамәлгә кертү комиссиясе* төзелә, аның карарлары респ-каның барлык совет оешмалары өчен мәҗбүри санала. ТАССР Мәгариф халык комис-тына «дәүләти аралашуларга яраштлы терминология һәм телеграф элемтәсе өчен татар әлифбасы булдыру» максатыннан комиссия төзү, совет хакимияте органнары һәм элемтә учреждениеләре хезмәткәрләренең татар телен өйрәнергә теләге булганнары өчен курслар оештыру, барлык 2 нче баскыч мәктәпләрендә татар телен укытуны кертү, ш.у. татар мәктәпләрендә, теләге булганнарга, рус телен укыту бурычы йөкләнә. Комис-т ш.у. элек ябылган татар мәктәпләрен (дини юнәлештәгеләреннән тыш) кабат ачарга, татар театрларын үстерүгә ярдәм итәргә күрсәтмә ала. Декрет нигезендә татар халкы күпчелекне тәшкил иткән торак пунктларда мәхкәмә эшенең, элемтә бүлекләре эшчәнлегенең (телеграммаларның татар телендә тапшырылуы һәм кабул ителүе һ.б.) татарча алып барылуы күздә тотыла. ТАССР ҮБК һәм ХКС чыгарган декретлар һәм карарлар русча һәм татарча нәшер ителергә тиеш була. Декретта рус теленең икенче дәүләт теле исәпләнгән татар теле б-н бер дәрәҗәдә кулланылырга тиешлеге әйтелә. Дәүләт оешмаларында эш кәгазьләренең, ш.у. үзара язма элемтәләрнең ТАССРда гамәлдә булган дәүләт телләренең берсендә алып барылуы таләп ителә, зарурлык туганда, тәрҗемәчеләр бюросы оештыру карала. Декретның гамәлгә кертелүе ТАССРның дәүләт, совет оешмаларында, уку йортларында татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтә. 1920 еллар ахы-

рында Декретны гамәлгә ашыру буенча алып барылган эшләр туктала.

Чыг.: Языковая политика в Республике Татарстан: Док. и материалы: 20–30-е гг. — Татарстан Республикасында тел сәясәте: Док. һәм материаллар: 20–30 нчы еллар. К., 1998.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**РЕСПУ́БЛИКА СПИДКА́ КАРШЫ́ ПРОФИЛА́КТИКА ҮЗӘГЕ́** (СПИД үзәге), ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында, махсус сәламәтлек саклау учреждениесе. 1989 елның 14 августында ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгы карары б-н оеша. ВИЧ-инфекцияле һәм СПИД-ассоциацияле авыруларга югары квалификацияле махсус консультатив-диагностик һәм дәвалау-профилактика ярдәме күрсәтә, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының оештыру-методик үзәге булып тора, респ-ка терр-ясендә ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш системасына җитәкчелек итә (ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы б-н берлектә комплекслы рәвештә профилактика чаралары оештыра, Сәламәтлек саклау министрлыгы учреждениеләренең гигиена тәрбиясе бирү буенча алып барган эшчәнлеген координацияли).

СПИД үзәгендә үз эченә ультратавыш ярдәмендә тикшерү кабинетын, серология, вирусология, клиник иммунология, гомуми клиник диагностика, молекуляр-биол. тикшеренүләр, микробиол. лаб-яләрен, эпидемиология, профилактика, ВИЧ-инфекция йөртүчеләрне мед.-социаль реабилитацияләү, мед. ярдәменең сыйфатын тикшерү бүлекләрен, «Ана һәм бала» үзәген эченә алган поликлиника эшли. Поликлиникада ел саен 40 меңләп кеше дәвалана. 2009 елдан СПИД үзәген модернизацияләү буенча актив чаралар күрелә, 2 яңа лаб-я сафка баса. Респ-ка күләмендә 33 лаб-я исәпләнә, аларда елына тулаем 3 млн. нан артык анализ ясала.

СПИД үзәгендә, Чаллы һәм Әлмәт шәһәрләрендәге ф-лларны да кертеп, 300 дән артык белгеч-табиб: инфекционистлар, эпидемиологлар, дерматовенерологлар, психологлар, психотерапевтлар, педиатрлар, иммунологлар, акушер-гинекологлар, социаль эш белгечләре һәм юрисконсульт эшли.

ТРда «AIDSNET» мәгълүмат системасы аша ВИЧ-инфекция мониторингы алып барыла, бу респ-када ВИЧ-инфекциягә бәйле халәтне он-лайн режимында анализлау һәм оператив рәвештә чара күрү мөмкинлеге бирә. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының 80 учреждениесеннән 80 кулланучыны уртак челтәр берләштерә.

СПИД үзәге авыруларны дәвалауның яңа ысулларын һәм технологияләрен гамәлгә кертә. 2008 елдан «Фиброскан» аппараты ярдәмендә бавыр фиброзы дәрәҗәсен инвазив булмаган юл б-н ачыклау буенча уникаль алым кулланыла. 2011 дә туберкулёзны башлангыч чорында ачыклау методикасы эшләнә (РФ буенча уйлап табулар Дәүләт реестрында 2431675 нче патент итеп теркәлә); вируска каршы көрәшнең нәтиҗәлелеген дару резистентлыгы аша ачыклау ысулы гамәлгә кертелә.

Үзәктә ТРның мед. кадрлары өчен ВИЧ-инфекция б-н бәйле темаларга (диагноз кую, авыруны дәвалау һәм кисәтү) укулар оештырыла. Респ-каның сәламәтлек саклау учреждениеләре хезмәткәрләре өчен табибләр һәм Җәзалар үтәтү федераль хезмәте учреждениеләре хезмәткәрләре өчен методик кӧнәр, семинар-киңәшмәләр үткәрелә. Үзәк ел саен ВИЧ-инфекцияне өйрәнүгә багышланган материаллар, ТР Сәламәтлек саклау учреждениеләре белгечләре өчен ТР һәм РФнең норматив документлары тупланган җыентыклар әзерләп чыгара, полиграфик продукция бастыра. Халыкның махсус төркемен тәшкил итүчеләрнең хәбәрдарлыгын күтәрү концепциясе кысаларында 12 видеоролик әзерләнә һәм алар респ-каның барлык терр-ясендә күрсәтелә.

2006 елдан СПИД үзәге республикакүләм әһәмиятле «Сәламәтлек» милли проектының «ВИЧ-инфекция, В һәм С гепатитларын кисәтү, ВИЧ авыруы очракларын ачыклау һәм авыруларны дәвалау» өлешен тормышка ашыру юнәлешендә эш алып бара. 1987 дән 2014 кә кадәр ТРда 16723 ВИЧ-инфекция очрагы теркәлә (100 мең кешегә — 428,4; РФдә — 515,2), 10508 кеше диспансер күзәтүендә тора. Исәптә торучыларның 36% ына карата вируска каршы актив дәвалау чаралары күрелә, әлеге төркемдәгеләр, дәвалау беркетмәләре нигезендә, югары технологияле тикшерү ысуллары һәм дәвалау чаралары б-н тулысынча тәэмин ителә.

Халыкара хезмәт оешмасы б-н берлектә, СПИД үзәге эш урыннарында ВИЧ/СПИД профилактикасы, ВИЧ-инфекцияле хезмәткәрләргә карата дискриминация очракларын кисәтү, ВИЧ-инфекция проблемасы булган гаиләләрдә ана һәм бала сәламәтлеге б-н бәйле мәсьәләләрне хәл итү чараларын күрә.

Респ-ка СПИД үзәге баш табибе ТР МК каршындагы ТРда ВИЧ-инфекция таралуны кисәтү б-н шөгыльләнүче оешмалар һәм хезмәтләр эшчәнлеген координацияләүче Оешмаара СПИДка каршы көрәш комиссиясенең җаваплы секретаре вазифасын да башкара.

Баш табиб: Н.И.Галиуллин (2009 дан).

*Н.И.Галиуллин.*

**«РЕСПУ́БЛИКА ТАТАРСТА́Н»** («Татарстан Республикасы»), көндәлек иҗтимагый-сәяси газета. Татарстанда рус телендә чыгучы әйдәп баручы басма. 1917 елның 13 апреленнән Казанда чыга. Исеме үзгәреп тора: 1917 нең 22 августында Вакытлы хөкүмәтнең җирле органнары тарафыннан ябылганга кадәр — «Рабочий», 1917 нең 11 ноябреннән — «Знамя революции» (1918 нең 14 июленнән аңа яңартылган «Рабочий» г-тасы кушыла), 1920 нең 1 маеннан — «Знамя труда», 1920 нең 30 июненнән — «Известия Ревкома Татарской ССР, губкома РКП(б) и Казанского горсовета», 1920 нең 29 сентябреннән — «Известия ТатЦика, обкома РКП(б) и Казанского Совета», 1924 нең 5 маеннан «Красная Татария», 1951 нең 5 августыннан «Советская Татария», 1993 нең 17 августыннан — «Р.Т.». Мөхәррирләре: В.А.*Тихомирнов* (1917), О.А.Цветкова (1917), К.Я.Грасис, П.Н.Ионов һәм И.Г.Мохов составындагы редколлегия (1917–18), В.Введенский (1918), составында Л.С.Агниев, Е.И.Вегер һәм А.И.Израилович булган редколлегия (1918), Л.С.Агниев (1918–19), П.Н.Ионов (1919), В.М.*Бахметьев* (1919–21), Д.А.Орлов (1922), Ю.А.Фемидин (1922–23), И.М.Бажанов (1923), Г.Цыпин (1925–26), Н.Пищальников (1926–27), Л.М.Рубинштейн (1927–30), П.Кушнер-Кнышев (1930), Л.Вульфсон (1930–32), И.Г.Бойцов (1932–33), Б.Красный (1933–34), И.М.Коган (1934–36), Г.Я.Беус (1936–37), В.Судаков (1937), К.П.Перов (1937–39), А.И.*Анушкин* (1940–45), А.М.Мальшаков (1945–53), М.А.Колодин (1953–63), Ш.Х.Хамматов (1963–67), А.И.*Клименков* (1967–74), Е.А.Лисин (1974–78, 1985–2004), Ю.Б.Щелыванов (1978–85), А.Н.*Латышев* (2004 тән).




«Республика Татарстан» газетасының Республика көненә багышланган бәйрәм саны. 2009.

Актив авторлар арасында — Б.Аитов, А.Бамунер, А.Барщевский, П.Бахтин, Ю.Белостоцкий, Г.Вәлиев, И.Ворошилин, В.Вылегжанин, В.Гудкова, М.Зарипов, Б.Зернит, М.Ильина, В.Куликов, Э.Ларичева, А.Малов, А.Сабиров, Н.Сорокин, Н.Соколов, А.Табейко, М.Спиридонов, Е.Целуйкина, Н.Кожевникова, И.Дёмина, Е.Чеснокова, А.Лебедев, А.Медведев һ.б. Газетада төрле елларда күренекле язучылар: Н.Асеев, Д.Бедный, М.Горький, С.Есенин, С.Заревой, М.Исаковский, С.Кирсанов, В.Маяковский, Л.Ошанин, Л.Сәйфуллина, М.Шолохов, И.Эренбург һ.б.ның, ш.у. җирле язучылар һәм шагыйрьләр: Г.Әпсәләмов, А.Алдан-Семёнов, Г.Бәширов, М.Бубеннов, Я.Винецкий, Н.Дәүли, М.Җәлил, Ә.Ерикәй, И.Заботин, Г.Кашшаф, В.Корчагин, К.Нәҗми, К.Лебедев, Р.Мостафин, З.Нури, С.Оков, Г.Паушкин, П.Радимов, М.Садри, Х.Туфан, С.Хәким, Н.Орешина, Р.Кутуй, Д.Вәлиев, Р.Вәлиев, Н.Алешков, Р.Харис һ.б.ның әсәрләре басыла. Газетада танылган партия, совет һәм профсоюз хезмәткәрләре, галимнәр, публицистлар, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре чыгыш ясый. Кушымталары чыга: 1920 дә «Известия Казанского губкома РКП(б)», «Бюллетень Татарского обласктома РКП(б)», «Еженедельник Известий Татарского ЦИК, обласктома РКП(б) и Казанского Совета», 1922 дә — «Красный боец», «Литературный листок», «Вечерние телеграммы», «Листок Наркомздрава», 1922–23 тә — «Официальный листок» г-талары, «Ёрш», «*Еженедельник литературы, искусства и науки*», ж-ллары,

«Рефлектор», 1923 тә — «Красная деревня» г-тасы, 1925 тә «Причал» ж-лы, 1926–27 дә — «Голос рабочего» г-тасы, 1927–28 дә — «Еженедельник» ж-лы («Красная Татария» г-тасы).

Газетаның төп тематикасын Россия, Татарстан һәм чит илләрнең иҗтимагый-сәяси тормышындагы вакыйгалар билгели. Эшчәнлегенең беренче айларында, демократик рев-циянең җиңүе һәм ике хакимиятлелек урнашу шартларында, «Рабочий» г-тасы Россиядә соц. рев-ция җиңүе өчен көрәшү һәм бөтен дәүләт хөкүмәтен Советлар кулына тапшыру идеяләрен пропагандалый. Ул Вакытлы хөкүмәтнең тышкы һәм эчке сәясәтен тәнкыйди бәяли һәм Вакытлы хөкүмәт боерыгы б-н ябыла. Аның 1917 нең 22 августындагы 40 нчы саны конфискацияләнә. 1917 елгы Окт. рев-циясенең беренче көннәрендә туган «Знамя революции» г-тасы совет хөкүмәтен ныгыту өчен көрәшә. Гражданнар сугышы елларында Ак армия һөҗүменә каршы көчләрне мобилизацияләүдә катнаша. Тыныч төзелеш чорында игътибар үзәгендә халык хуҗалыгын торгызу, нэп, милләтләр һәм халыкларның икътисади, мәдәни тигезсезлеген бетерү, халыклар дуслыгын ныгыту, илне *индустрияләштерү, культура революциясе, крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү*, сугышка кадәрге бишьеллыкларны вакытыннан алда үтәү, совет кешеләрен соц. киләчәккә ышаныч рухында тәрбияләү, кулга корал тотып Ватанны саклауга әзерлек мәсьәләләре тора. Бөек Ватан сугышы елларында газетада Татарстан халкының сугыштагы һәм тылдагы батырлыклары киң яктыртыла. Сугыштан соңгы чорда һәр санда респ-ка сәнәгатенең яңа тармакларының үсеше һәм нефть, нефть химиясе, энергетика, машина төзелешендәге проблемалар бәян ителә. Авыл хуҗалыгын үстерү, мәдәни төзелеш мәсьәләләренә зур игътибар бирелә. Хәзерге вакытта «Р.Т.» респ-ка һәм илнең иҗтимагый, икътисади һәм мәдәни тормышындагы мөһим вакыйгаларны яктырта. Газета беренчеләрдән булып ТР Президенты указларын, ТР Дәүләт Советы кабул иткән законнарны, ТР МК карарларын рус телендә бастыра. Атнага бер тапкыр хәзерге һәм үткәндәге тарихи шәхесләр, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, игътибарга лаеклы вакыйгалар турында очерклар, хикәяләр булган күпбитле рәсемле саннары чыга.

*Әд.:* Фабрика печатного слова. К., 1923; Каримова С.К. Газета «Рабочий» в борьбе за массы. К., 1957; «Советской Татарии» — полвека // Коммунист Татарии. 1967. № 4; Многонациональная советская журналистика. М., 1975; Насыров Т.М. Октябрь и печать Татарии. К., 1975; Фасахов К.М. С жизнью в ногу (Периодическая печать Татарии в восстановительный период). К., 1979.

*Т.М.Насыйров.*

**РЕСПУ́БЛИКА ФӘННИ́ КИТАПХАНӘСЕ́**, к. *Татарстан Республикасының милли китапханәсе.*

**РЕСПУ́БЛИКА ҺӘЛАКӘТЛӘ́Р МЕДИЦИ́НАСЫ ҮЗӘГЕ́**, к. *Катастрофалар медицинасы.*

**РЕСПУ́БЛИКА ЯШҮСМЕРЛӘ́Р КИТАПХАНӘСЕ́**, Татарстан Республикасы мәдәниятенең дәүләт бюджет учреждениесе, Казанда. ТАССР Мәдәният министрлыгының 1976 елның 16 декабрь боерыгы нигезендә оеша, 1978 нең 29 июнендә Яшьләр үзәге бинасында ачыла. 1995 тә Р.я.к.нә 1039,8 $м^2$ мәйданлы аерым бина бирелә. Структурада 8 бүлек: фондларны оештыру, укучыларга хезмәт күрсәтү, китапханә-библиографик һәм мәгълүмати процессларны автоматлаштыру, белешмә-библиографик, инновацион-методик, массакүләм чаралар оештыру, яшьләр өчен мәгълүмат үзәге, «Айсберг» социаль-әхлакый китапханә үзәге; штатта 78 кеше.

2014 кә Р.я.к. фондында 105 мең данә китап, 110 исемдә вакытлы матбугат басмалары исәпләнә. Китапханәнең уку йортларында, интернатларда, лагерьларда, тәрбия колонияләрендә 22 китапханә пункты бар. Аларның хезмәтләреннән елына 175 меңнән артык кеше (85% ы — 25 яшькә кадәрге яшьләр) файдалана.

**РЕСПУ́БЛИКАНЫҢ ЗАПА́С А́РМИЯСЕ**, 1919 елның августында Кызыл Армия частьларын тулыландыру һәм стратегик резерв булдыру максатыннан төзелә. 1919 ның сентябреннән 1920 нең декабренә кадәр штаб Казанда эшли. Командиры — Б.И.*Гольдберг*. Р.з.а., Казаннан тыш, Алатырь, Ардатов, Саранск, Сарапул, Сенгилей, Сембер, Тимирязево, Шихраны (Канаш) шәһәрләрендә урнаша. Алардагы хәрби отрядлар запас армия карамагына тапшырыла. Р.з.а. хәрби әзерлек узганнан соң мобилизацияләнүчеләр хисабына тулыландырыла. Командирлар составы Казандагы һәм Идел буеның башка шәһәрләрендәге кыска сроклы курсларда әзерләнә. Кече командирлар составы өйрәнү полкында укытыла. Командирлар курсын тәмамлаучыларга «кызыл командир» дәрәҗәсе бирелә. Р.з.а. фронтка 2 укчы һәм 2 атлы дивизия, 26 укчы һәм 4 атлы бригада, 4 укчы һәм 16 атлы полк, 30 эскадрон, 20 артиллерия дивизионы, 17 батарея, 1 авиаотряд, 1 понтон полкы, 200 дән артык марш батальоны, 12 пулемёт командасы һ.б. әзерләп озата. Башкомандующий С.С.Каменев исәпләвенчә, иң сугышчан фронтлар 40% ка Р.з.а. тарафыннан тәэмин ителәләр, гомумән алганда, барлык фронтларның 34% составы запас армия хисабына тулыландырыла. Сугышчан резерв әзерләүдән тыш, Р.з.а.нә Мәскәү–Казан–Екатеринбург линиясендәге тимер юл транспортына хезмәт күрсәтү бурычы: паровозлар һәм вагоннар ремонтлау, җимерелгән станцияләр, күперләр, юлларны торгызу һ.б. йөкләтелә. Р.з.а. частьлары ш.у. 1920 елда *«Сәнәкчеләр» фетнәсен* бастыруда катнашалар. Армия политбүлеге тарафыннан «Красный боец» (1919–20) г-тасы нәшер ителә. 1920 нең декабрендә Р.з.а. идарәсе Идел буе Хәрби округы штабы б-н берләштерелә.

*Әд.:* Каменев С.С. Записки о гражданской войне и военном строительстве. М., 1963; Евдокимов В.Е. Создание Запасной армии Республики в Среднем Поволжье // Вопросы истории и историографии чувашского народа. Чебоксары, 1973; Дмитриев П.Н. Создание стратегических резервов Красной Армии в годы гражданской войны // Воен.-ист. журн. 1974. № 6; Гражданская война и военная интервенция в СССР: Энцикл. М., 1987.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**РЕСТАВРА́ЦИЯ** (архит-ра), бозылган, ватылган яки җимерелгән архит-ра истәлекләрен һәрьяклы фәнни тикшеренүләр нәтиҗәләренә нигезләнгән, элеккечә яки якынча рәвештә ныгыту һәм торгызу буенча эшләр комплексы. Европада архит-ра истәлекләрен реставрацияләү теориясе һәм практикасы 15 йөздән, антик биналарны саклауга ихтыяҗ тугач үсеш ала; 18 йөздән ш.у. урта гасырлар истәлекләре дә тарихи хәзинә сыйфатында карала башлый; 19 йөзнең 1 нче яртысында Р. истәлекләрнең төп үрнәкләрен саклау һәм ачыклауның аеруча максатчан булуы б-н аерылып тора; бу вакытта Р. практикасында беренче тапкыр реставрацияләү хезмәтләрен төп нөсхәләрдән аеру өчен башка төрле материаллар һәм формаларның гадиләштерелгән үрнәкләре кулланыла. 19 йөздә охшашлык буенча реставрацияләү ысулы барлыкка килә. Көнбатыш Европада Р. теориясенә һәм практикасы үсешенә иң көчле йогынты ясаучы дип Э.Э.Виолле-ле-Дюк исәпләнә: аның тарафыннан эшләнгән истәлекләрне конструкцияләренең төзек хәлдә тотылуы һәм соңрак куелган архитектур өстәмәләрнең истәлек тарихы шаһиты буларак саклануы хисабына ныгыту принциплары архитектур Р. өлкәсендә яңалык булып тора. 19 йөз уртасында Көнбатыш Европада истәлекнең төзелү чорына ят булган үзгәрешләрне бетерү хисабына стилистик бердәмлекне тулысынча торгызуны максат иткән стилистик (романтик) Р. алымы киң тарала. Ул чакта архит-ра Р.се, һөнәр буларак, архит-ра гыйлеме һәм гамәле өлкәсеннән аерылып каралмый. 19 йөз ахырында архит-ра истәлеге урынында тарихи чынлыгын һәм кыйммәтен югалткан, тышкы яктан аңа охшаш модель хасил иткән стилистик Р.нең ялгышлык булуы ачыклана.

Россиянең Европа мәдәниятенә тартыла башлавы б-н, 18 йөз башында үткәннәргә карата кызыксыну көчәя. Пётр I архит-ра истәлекләрен саклау турында берничә фәрман чыгара. Борынгы архит-ра төзелешләренең кыйммәтен аңлау 18 йөз дәвамында Р. эшчәнлегенең үсешенә китерә, әмма башлангыч чорда ул алдан тикшеренүләр уздырылмаган стилистик Р. нормаларына тартыла. 19 йөз ахырында Россиядә Р. алымнары үсеше Мәскәү археол. җәмгыятенең хезмәтләрендә архит-ра истәлекләрен реставрацияләү турындагы хисаплар б-н бергә бара. Н.В.Солтанов, А.М.Павлинов, В.В.Суслов һ.б. рус архит-расының шул чордагы күренекле тикшеренүчеләреннән санала. 20 йөз башында Россиядә вәкилләре Ф.Ф.Горностаев, Д.В.Милеев, И.П.Машков, И.В.Рыльский, Д.П.Сухов булган Европа дәрәҗәсендәге Р. мәктәбе барлыкка килә. Шушы мәктәп базасында совет чоры Р.се башлана. Аның катгый фәнни принципларда формалашуында И.Э.Грабарь җитәкчелегендәге Үзәк дәүләт Р. остаханәләре (1920 еллар уртасы) оешмасы мөһим роль уйный. Сугыштан соңгы елларда Бөек Ватан сугышы вакытында фашистлар тарафыннан җимерелгән бик күп истәлекләрне яңадан торгызу зарурлыгы кискен тора. Архит-ра истәлекләрен файдалануга



С.Н. Реформатский.



М.Г. Речапова.

ярашлы итеп көйләү аларны саклауның беренчел шартына әверелә.

Дәвамлы үсеш чорында заманча Р.нең теоретик алшартлары барлыкка килә. Реставрацияләү максатының авторның иҗади күзаллауларын гамәлгә ашыру түгел, ә бәлки архит-ра истәлегенең зыян күргән өлешләрен, еллар узу б-н барлыкка килгән үзгәрешләрне һәм фәзаи-архитектур мохитта урнашкан бәйләнешләрне торгызу икәнлеге ассызыклана. Р. алдына куелган гомуми таләпнең асылы объектның үзенчәлеген мөмкин кадәр саклап калудан гыйбарәт була. Соңрак барлыкка килгән үзгәрешләр чорның мәдәни үзенчәлекләрендәге тарихи һәм сәнгати кыйммәтләр чагылышы дип кенә түгел, истәлекнең состав өлешләре сыйфатында мөһим дип танылалар.

Р. хәзерге заман төзелешләреннән күпкә аерылып торган махсус ысуллар б-н үткәрелә. Архит-ра истәлекләренә караган эшләр 3 төргә бүленә: Р., консервация һәм ремонт эшләре. Консервация — уникаль истәлекләрне гамәлдәге халәттә саклауны әченә алган төп эш төре (нигезен һәм фундаментын саклау, терәгеч кормаларын беркетү, иске материалларны ныгыту һ.б.). Якын арада истәлеккә җимерелү куркынычы янаганда, консервация вакытында терәк кую, түбә ябу эшләре карала. Ремонт эшләре вакытында корылманың тышкы күренеше үзгәрешсез кала. Р., истәлекнең сәнгати сыйфатларын тулырак итеп ачу һәм гамәлдәге күренешен үзгәртү максатында, ремонт һәм реставрация эшләре башкаруны үз әченә ала. Р. эшләре ике өлештән тора: истәлекнең асылын соңгы елларда барлыкка килгән үзгәрешләрдән, күренешен боза торган элементлардан арындыру (фрагментлы Р.) һәм аның югалган элементларын тергезү (тулы Р.). Соңгысы, башлыча тиешле документлары сакланган очракта, күптән түгел җимерелгән истәлекләрне торгызганда файдаланыла. Аның өчен архит-ра истәлеге төзелеше вакытына яраклы традицион материаллар, төзелеш алымнары һәм техникасы кулланыла. Р. борынгы төзелеш технологиясен һәм аны яңадан кора белүне күз алдында тота.

Татарстан җирендә беренче Р. эшләре Пётр I фәрманы буенча, 18 йөзнең 1 нче яртысында үткәрелә: Болгардагы Зур һәм Кече манара, Алабугадагы «Шайтан каласы», Казандагы Сөембикә һәм Спас манаралары, Петропавел соборы (19–20 йөз башы) һ.б. реставрацияләнә. Татарстандагы фәнни-реставрация үзәге 1950 еллар ахырыннан Татарстан махсус фәнни-реставрация җитештерү остаханәсе булып әверелә (1991 дән — Махсус фәнни-реставрация идарәсе). Казан Кремле, Зөя шәһәрендәге Успение һәм Иоанн-Предтеча монастырьлары, Болгар тарихи-архит-ра музей-саклаулыгы корылмалары һ.б. реставрацияләнә. С.С.*Айдаров*, Р.В.*Билалов*, С.Ә.Мамлиева һ.б. әйдәп баручы архитектор-реставраторлардан саналалар.

*Әд.:* Реставрация памятников архитектуры. М., 2000. *Х.Г.Надыйрова.*

**РЕФЕРЕ́НДУМ**, гражданнарның закон проектлары, гамәлдәге законнар һәм дәүләт дәрәҗәсендәге башка мәсьәләләр буенча бөтенхалык тавыш бирүе. Ирекле сайлаулар б-н беррәттән, халык хакимиятенең иң югары турыдан-туры чагылышы. Респ-ка Р.ын үткәрү *Татарстан Республикасы Конституциясе* һәм ТРның «Референдум турында» 1991 елның 29 ноябрь һәм 2001 нең 25 октябрь законнары б-н тәртипкә салына. Респ-ка Р.ын уздыру тәкъдиме ТР Президенты, ТР Дәүләт Советы депутатларының өчтән бер өлешеннән яисә Р.да катнашу хокукына ия гражданнарның 2% тан да (2001 гә кадәр — 100 меңнән дә ким түгел) ким булмаган өлеше тарафыннан белдерелә ала. Респ-ка Р.ын әзерләү һәм уздыруны ТР Үзәк сайлау комиссиясе, терр. һәм участок Р. комиссияләре респ-ка бюджеты хисабына гамәлгә ашыра. Респ-ка Р.ын ТР Дәүләт Советы (1995 кә кадәр — ЮС) билгели. Гомуми, тигез һәм туры ихтыяр нигезендә яшерен тавыш бирү юлы б-н уздырыла. Р.да катнашучыларга карата да сайлаучыларга куелган таләпләр (18 яшь тулган булу, эшкә яраклылык һ.б.) куела. Исемлектәге сайлаучыларның 50% тан артыгы тавыш бирсә, респ-ка Р.ы карары кабул ителгән дип исәпләнә һәм Үзәк Р. комиссиясе тарафыннан рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән көченә керә: ул гомуммәҗбүри булып санала һәм өстәмә раслауга мохтаҗ түгел, ТРның бөтен терр-ясендә гамәлдә була һәм Р.да башка карар кабул итү юлы б-н бетерелә, үзгәртелә яисә мәхкәмә тәртибендә дөрес булмаган дип танылa ала.

ТРда беренче мәртәбә Р. 1991 нең 17 мартында СССРны саклап калу турындагы мәсьәлә буенча уздырыла. 1992 нең 21 мартында ТР дәүләт статусы хакында респ-ка Р.ы үткәрелә. Тавыш бирүдә Р.да катнашу хокукына ия гражданнарның 82% ы катнаша, аларның 61,4% ы Татарстанның социаль-икътисади һәм сәяси статусын күтәрү өчен тавыш бирә. Респ-ка Р.ы нәтиҗәләренә сылтамалар РФ һәм ТР арасында «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары б-н Татарстан Респ-касы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында шартнамә» (1994) һәм «*Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында*» (2007) федератив килешүләрендә урын ала.

*Е.Б.Долгов.*

**РЕФЛЕКСОТЕРАПИ́Я**, к. *Акупунктура*.

**«РЕФЛЕ́КТОР»**, журнал. к. «*Республика Татарстан*».

**РЕФОРМА́ТСКИЙ** Александр Николаевич (25.11.1864, Кострома губ. Борисоглебское а. — 27.12.1937, Мәскәү), химик-органик, проф. (1893), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1935). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1888), Мәскәү (1889 дан), Гейдельберг (1894, Германия) ун-тларында эшли; Мәскәү югары хатын-кызлар курслары профессоры (1898–1918), бер үк вакытта А.Л.Шанявский исем. Мәскәү халык ун-ты профессоры (1901–19) һәм Мәскәү практик академиясе директоры (1901–16). 1918 дән 2 нче Мәскәү ун-тында (1930 дан — Мәскәү нәзек химик технол. ин-ты). Хезмәтләре органик химиягә карый. Р. болгар роза маеның составын билгели (В.В.Марковников б-н бергә), ароматик альдегидларны өйрәнә, α-бромпропион к-тасының этил эфирына иодлы аллилның һәм цинкның тәэсирен тикшерә. Майлар рәтендәге бер атомлы чиксез спиртларны синтезлый. «Научно-технический вестник», «Сообщения научно-технического отделения при ВСНХ» ж-ллары мөхәррире (1919 дан).

Х е з м.: Исследование болгарского розового масла. СПб., 1892 (автордаш); Органическая химия: Краткий начальный курс. М.–Л., 1930; Неорганическая химия: Учеб. М.–Л., 1933.

*Әд.:* В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Химики: Биогр. спр. Киев, 1984; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

**РЕФОРМА́ТСКИЙ** Сергей Николаевич (20.3.1860, Кострома губ. Борисоглебское а. — 27.12.1934, Мәскәү), химик-органик, химия фән. д-ры (1891), СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1928). Химик-органикларның Киев мәктәбенә нигез салучы. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1882), шунда ук эшли, 1889–90 елларда — Гейдельберг һәм Лейпциг ун-тларында (Германия). 1891 дән Киев ун-ты профессоры, бер үк вакытта, 1906–19 да, Киев югары хатын-кызлар курслары профессоры. Хезмәтләре металлорганик синтезга карый. Р. өченчел спиртларның изотөзелеш углеводородларына кадәр кайтарылуын тикшерә. 1887 дә альдегидларга яки кетоннарга цинк һәм α-галогенкарбон к-таларының катлаулы эфирлары б-н тәэсир итеп, β-оксикарбон к-талары эфирларын синтезлый (Реформатский реакциясе). Реакциягә чикле һәм чиксез, төрле функциональ төркемнәр (галоид, алкокси-, нитротөркем һ.б.), стероидлар һәм башка классларның кушылмалары катнашкан алифатик, алициклик, ароматик, майлы-ароматик, гетероциклик кетоннар һәм альдегидлар керә. Альдегидларның реакциягә сәләте кетоннарныкына караганда көчлерәк. Галогенкарбон к-талары эфирлары урынына аларның винилоглары яки актив галогены булган кушылмалар файдаланылырга мөмкин. Реакция β-оксик-талар һәм α, β-чиксез к-талар эфирларын синтезлау өчен, шулай ук углерод чылбырын озайту һәм тармакландыру ысулы буларак кулланыла. Әлеге реакция ярдәмендә Р. оксик-талар һәм аларның кушылмалары классының төрле үрнәкләрен (β-лактоннар, β-кетокислоталар һ.б.), ш.у. катлаулы органик кушыл-

малар (мәс., витаминнар, гормоннар) синтезлый. Күп атомлы спиртлар, үсемлекләрдән табигый каучук алуы турында хезмәтләр сериясен бастырып чыгара. Д.И.Менделеев исем. Бөтенсоюз химия җәмгыятенең Киев бүлеген оештыра (1933). Киев ун-ты каршындагы Физика-химия җәмгыяте рәисе (1910–16, 1920–33).

Х е з м.: Начальный курс органической химии. Киев, 1930.

*Әд.:* В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

**РЕЧА́ПОВА** Мансура Габдрахман кызы (21.8.1923, Омск өлкәсенең Седельников р-ны Юрто-Уйск а. – 29.5.2014, шунда ук), тракторчы-машинист, Соц. Хезмәт Герое (1971). Тракторчылар курсын тәмамлый (1939). 1940–58 елларда Седельников МТСнда эшли, 1958–75 елларда Седельников р-нының Артём Избышев исем. к-зында эшли. Герой исеме а.х. җитештерүен үстерүдә ирешкән уңышлары, игенчелек һәм терлекчелек продукциясен дәүләткә сатуда бишьеллык планны үтәгәне өчен бирелә (1966–70). Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Омичи — Герои Социалистического Труда. Омск, 1990. Вып. 2; М о р о з о в а Н.Ф., Ш е в ч е н к о Р.С. В заиртышских далях. Омск. 1999.

**РЕЧНО́Й** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 12 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 321 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1688 дән мәгълүм; рев-циягә кадәрге чыганакларда Богоявленский исеме б-н дә билгеле; 1967 гә кадәр Остолопово исемен йөртә. Башта халкы Казан Кизик монастырена карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, йон эрләү, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Богоявление чиркәве (1783 тән эшләгән агач чиркәү урынында 1880 дә төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход һәм земство (1875 тә ачыла) мәктәпләре, 1 казна шәраб һәм 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4708 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Алексеев волостенда, 1920 дән — ТАССРның Лаеш, 1921 дән — Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан — Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 395 ир-ат; 1859 да — 2331, 1897 дә — 1877, 1908 дә — 2357, 1920 дә — 2465, 1926 да — 2108, 1938 дә — 1186, 1949 да — 897, 1958 дә — 689, 1970 тә — 505, 1979 да — 441, 1989 да — 400, 2002 дә — 382 кеше.

**«РЕЧЬ БЛАГОДА́РСТВЕННАЯ»** («Рәхмәт сүзе»), 18 йөз китап ядкәре. Казанда *Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)* б-н бәйле рәвештә оешкан тикшерү комиссиясе составында булган Г.Р.*Державин* тарафыннан иҗат ителә. Казан дворяннары үзләренең шәхси акчаларына һәм крепостной крәстияннәр хисабына (200 җаннан 1 әр кеше) Е.И.*Пугачёв* отрядлары б-н көрәшү өчен атлы корпус оештыралар. Әлеге патриотик гамәлне белеп алгач, Екатерина II 1774 елның 22 февралендә Манифест чыгара, анда Казан дворяннарына рәхмәт белдерелә, ш.у. Казан губернасындагы сарай волостьларыннан, «шул губернаның алпавыты буларак» рекрутлар җыю турында күрсәтмә бирә. Аның үрнәгенә Казан сәүдәгәрләре һәм мещаннары, башка шәһәр дворяннары иярә. Манифест тантаналы рәвештә укыла. Әлеге очрак өчен Державин тарафыннан язылган «Р.б.»ны губерна дворяннары башлыгы укый. «Р.б.» зур тәэсир калдыра һәм 1774 нең 25 февралендә «Прибавление Санкт-Петербургских ведомостей»да аерым бит итеп бастырыла. Бер үк вакытта «St. Petersburgische Zeitung» г-тасында немец телендә нәшер ителә (немец телендә аны Державин үзе язган дип исәпләнелә). Брошюра сыйфатында аерым биттә исеме б-н бирелгән басма нөсхә Казанның үз басмасы кебек кабул ителә (Сопиков В.С. «Россия библиографиясе тәҗрибәсе...» — Сопиков В.С. «Опыт российской библиографии...», 1–4 бүлек, СПб., 1816). Китап белгече Н.П.Лихачёв брошюраны, Казанда басылуына шикләнеп, «Казан матбугатының уйдырма башлангычы» дип атый. Тик бу фаразны яклаучы аргументлар да бар: 1767 дә Екатерина II нең Казанга килүе хөрмәтенә торгызылган триумфаль капкалар сурәтләнгән «китапчыклар» таратыла. Державинның әсәре император тарафыннан лаеклы бәяләнә. Ул «Р.б.»ны «...күркәм уйлар б-н тулган», дип билгеләп үтә.

*Әд.:* П и н е г и н М.Н. Казань в её прошлом и настоящем. К., 1890; Л и х а ч ё в Н.П. Мнимый первенец Казанской печати: Библиогр. заметки. К., 1897. *И.А.Новицкая.*

**РЕЧЬ ПОСПОЛИ́ТА МӨСЕЛМАННАРЫ́ БЕРЛЕГЕ́**, 1925–39 елларда Варшавада эшчәнлек алып бара. *Бөтенпольша мөселманнары гминасы вәкилләре съездында, Мөселманнар берлеге* б-н *Мөселманнарның дини берлеге* берләшү нәтиҗәсендә барлыкка килә. Польша-Литва татарлары мөфтияте бүлеге вазифасын үти, ил эчендә һәм чит илләрдә аның исеменнән чыгыш ясый, Польшада мөселман диаспорасының дини тормышына җитәкчелек итә. *Речь Посполита татарларының мәдәни-агарту берлеге* б-н вәкаләтләр бүлешү мәсьәләсендә каршылыкта булуы сәбәпле, Р.П.м.б.нең эшчәнлеген легальләштерү 1936 га — Сенат берлек эшчәнлеген хуплаган закон кабул иткәнчегә кадәр кичектереп килә. Р.П.м.б.нең хөкүмәт тарафыннан танылуы барлык Польша мөселманнары өчен дини инануларына яңа хокукый нигез биргән вакыйга буларак кабул ителә.

*Я.Я.Гришин.*

**РЕЧЬ ПОСПОЛИ́ТА ТАТАРЛАРЫНЫ́Ң МӘДӘНИ́-АГАРТУ́ БЕРЛЕГЕ́**, Польша-Литва татарларының 1926–39 елларда эшчәнлек алып барган җәмәгать оешмасы. *Бөтенпольша мөселманнары гминасы вәкилләре съездында* (1925 елның 3 дек.) төзелә. 1928 ел ахырында Берлекнең 1 нче съезды уздырыла, анда О.*Крычыньский* җитәкчелегендә Үзәк совет сайлана, татар музееn ачу һәм «*Рочник Татарски*» мәҗмугасын чыгару карары кабул ителә. Польшаның Польша-Литва татарлары тупланып яшәгән төбәкләрендә оешманың 20 бүлекчәсе барлыкка килә. Берлек аларның иҗтимагый-мәдәни тормышына җитәкчелек итә, китапханәләр ача, үзешчән сәнгать коллективлары туплый. «*Жиче Татарске*» ж-лын нәшер итә. Берлек әгъзалары Польша-Литва татарларына кагылышлы тарихи чыганаклар һәм ядкәрләрне барлау һәм туплау, тарихи истәлекләрне саклау буенча зур эш алып баралар. 1929 да Вильнода (1939 дан — Вильнюс) Берлек тарафыннан халык музее ачыла, аның экспозицияләре татар нәселләре вәкилләренең бүләкләреннән тора, архивында 16–17 йөзләргә караган 50 дән артык документаль ядкәр саклана. Берлек эшчәнлеге Польша-Литва татарларын этник төркем кысаларында берләштерүгә хезмәт итә.

*Я.Я.Гришин.*

**РЕШЕ́ТНИК** Ольга Алексеевна (7.3.1951, Сахалин өлкәсенең Оха ш.), микробиолог, техник фән. д-ры (1992), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2001). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1973), шунда ук эшли. 1980 елдан Казан технол. ун-тында, азык-төлек җитештерү технологиясе каф. мөдире (1997 дән). Хезмәтләре микроорганизмнар үсешендә биостимуляторлар йогынтысын өйрәнүгә һәм биол. актив матдәләр биосинтезына карый. Р. тарафыннан микроб күзәнәкләренә синтетик антиоксидантлар һәм нуклеодеполимераза ферментлар хәрәкәтенең мөмкин булган механизмнары өйрәнелә; специфик булмаган хәрәкәт биостимуляторларын куллану нигезендә бер күзәнәкле организмнар аксымы, ш.у. аминокислоталар алу технологияләре камилләштерелә. Уйлап табуга 15 патенты һәм авторлык таныклыгы бар. М.Җәлил исем. Татарстан комсомолы бүләге лауреаты (1978).

Х е з м.: Влияние антиоксиданта на рост и состав липидов дрожжей Saccharomyces cerevisiae в различные фазы развития культуры // Изв. РАН. Сер. биол. 1997. № 2 (автордаш); Оценка эффективности хлебопекарного улучшителя окислительного действия // Хлебопродукты. 1999. № 8; Эффективность использования янтарной кислоты в производстве ликёроводочных изделий из плодово-ягодного сырья // Изв. вузов. Пищевая технология. 2001. № 2/3 (автордаш).

**РЕ́ШЕТОВ** Юрий Сергеевич (12.1.1942, Мари АССРның Сернур р-ны Сернур пос.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1992), проф. (1992). Казан ун-тын тәмамлый (1968); шунда ук (1972 елдан) дәүләт һәм хокук теориясе һәм тарихы кафедрасында эшли, 1987–2015 тә каф. мөдире. Хезмәтләре хокукый көйләү һәм хокукны гамәлгә ашыруның теоретик һәм тарихи проблемаларына карый. 1990–95 тә ТР ЮС депутаты.

Х е з м.: Механизм правореализации в условиях развитого социализма. К., 1980; Реализация норм советского права: Системный анализ. К., 1989.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**РЖАВЕ́Ц** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 8 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда

112 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. Троица гыйбадәтханәсе. 1930 елларда нигез салына. 1950 еллар уртасында Куйбышев сусаклагычы астында калган Яңа Мордва авылы халкының бер өлеше Р.ка күченә. Оештырылган көннән Куйбышев р-нында. 1991 нең 4 октябреннән Спас р-нында. Халык саны: 1938 дә — 65, 1949 да — 92, 1958 дә — 362, 1970 тә — 319, 1979 да — 217, 1989 да — 168, 2002 дә — 132 кеше.

**РЖЁВСКАЯ** Галина Фёдоровна (1.3.1930, Үзбәкстан ССР, Коканд ш. — 3.1.2000, Казан), фармаколог, мед. фән. д-ры, проф (1974). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), Әлмәт шәһәр хастаханәсендә табиб-терапевт булып эшли. 1955 елдан Казан мед. ин-тының фармакол. кафедрасында. Хезмәтләре фосфорорганик кушылмалар фармакологиясенә карый. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы һәм 2 патенты бар. Нерв-психика авыруларын дәвалау өчен препаратлар уйлап табу һәм сынаучы авторларның берсе; фосфабензид транквилизаторын сәнәгать җитештерүенә кертүдә катнаша (препарат СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләренә лаек була).

Х е з м.: Сравнительная фармакологическая характеристика некоторых этилидеглицериновых эфиров диэтилфосфорной кислоты // Фармакология и токсикология. 1959. № 4; Противовирусное действие хлофосфеналя // Казан. мед. журн. 1969. № 4 (автордаш); Фармакологическая характеристика транквилизирующего действия гидифена // Фармакология и токсикология. М., 1980. Т. 64, № 4 (автордаш).

**РИВАЯ́ТЬ** (гарәп. رواية), фольклор жанры; тарихи шәхесләр, вакыйгалар, төбәкләр турында нәселдән нәселгә күчеп, телдән сөйләнә торган хикәя. Р. үзләре шаһит булган вакыйгаларда катнашкан кешеләр сөйләве җирлегендә барлыкка килеп (легендадан аермалы буларак), сәнгатьчә эшкәртелә. Татар Р.ләренең күпчелеге халык тарихы б-н бәйле. Тарихи Р.ләрнең тематик төркемнәре халык тарихының төп этапларына тәңгәл килә. Борынгы Р.ләр Идел буе Болгар дәүләте чоры турында хикәяли (мәс., «Болгар каласының корылуы», «Белемле кеше»). Аның башкаласының барлыкка килүен кайбер Р.ләр Искәндәр Зөлкәрнайн (Александр Македонский), ә җимерелүен Аксак Тимер исеме б-н бәйли («Болгарның харап булуы», «Кырык кыз» һ.б.). Р.ләрнең күпчелеге Казан ханлыгы чорына багышлана. Аларда ш.у. Аксак Тимер исеме очрый («Утсыз кайный торган казан»; «Туйбикә казаны» һ.б.). Р.ләрнең күпчелеге Казан ханбикәсе Сөембикә («Сөембикә»; «Патша хәйләсе» һ.б.), Казанны басып алган Явыз Иван («Явызлыгы башына җиткән»; «Явыз Иван ничек Казанга сугыш ачкан» һ.б.) турында хикәяли. Р.ләрдә Рус дәүләтенә Себер ханлыгы кушылу тарихы чынбарлыктагы вакыйгалардан шактый аерылып, үзгәртеп аңлатыла («Бараба халкы»; «Күчем хан» һ.б.). Крәстиянннәрнең баш күтәрүләренә багышланган тематик төркемгә «намуслы юлбасарлар» турындагы Р.ләр керә. Аларның геройлары — баш күтәрүчеләр отряды җитәкчесе Салават Юлаев, аның отрядыннан Әпсәләм Аитов, Е.И.Пугачёвның көрәштәше Бәхтияр Канкаев һ.б. кебек чын тарихи шәхесләр («Миндулла куышы»; «Юлай карагае» һ.б.). Гаилә-көнкүреш Р.ләре татар халкының көндәлек тормышына, гаиләдәге тәртипләргә багышлана («Сак-Сок көе», «Мәрьямкәй белән Булат»; «Налог өчен сатылган кызлар» һ.б.). Топонимик Р.ләр табигать объектлары — таулар, ерымнар, сазлык, болын, елга, күлләр («Мәликә чокыры», «Батырша үзәне», «Баллы елга», «Сәрби күле»), торак пунктлар («Бакырчы», «Мамадыш», «Андреевка» һ.б.) исемнәренең тарихына багышлана. Р.ләрне 19 йөз уртасында В.В.Радлов өйрәнә башлый («Төрки кабиләләрнең халык әдәбияты үрнәкләре», «Образцы народной литературы тюркских племён», 1–10 бүлек, СПб., 1866–1907), аларны ш.у. К.Насыйри дә өйрәнә. Татарстанда һәм Россиядә татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә Р.ләр өйрәнү б-н ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты шөгыльләнә.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987; Болгар, Казан төшми телләрдән: Риваятьләр һәм легендалар // Татар халык иҗаты: Хрестоматия. К., 2005.

*Ф.И.Урманчеев.*

**РИ́ВКИНД** Аким Иосифович (29.3.1921, Казан — 10.9.1973, шунда ук), физик, физика-матем. фән. д-ры (1963), проф. (1970). Мәскәү энергетика ин-тында укый (1938–41), Мәскәү элемтә инженерлары ин-тын тәмамлый (1942). 1947 елдан СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында, 1965 тән төш магнетизмы лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре электролит эремәләрендә төш релаксациясенә карый. Р., беренче булып (1954), парамагнетик тозлар эремәләрендә водород төшләренең релаксацион магнит характеристикаларының парамагнетик ионнарның якын тирәлеген чагылдырганын күрсәтә. Эреткеч төшләренең релаксация күрсәткечләрен парамагнетик эремәләрнең структурасын тикшерүдә куллану мөмкинлеген ачыклый; ванадил тозларының сыегайтылган эремәләрендә ачылыкны арттыра барган саен, спин-алмашу бәйләнеше коэффициентының күп тапкырлар үсүен билгели. Химик комплекслардагы броун әйләнешенең характерлы ешлыгы түбәнәю яисә лармор ешлыгы арту б-н спектр формасының асимметриясе кочәю күренешен билгели. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Об исследовании комплексообразования в растворах методом протонного резонанса // Докл. АН СССР. 1954. Т. 98, № 1 (автордаш); Протонный резонанс в неводных растворах парамагнитных солей // Докл. АН СССР. 1957. Т. 117, № 3; Об отсутствии точного зеркального равенства между оптическими антиподами // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1970. Т. 11, № 1.

**РИГО́РИН** (чын фамилиясе Лихтман) Григорий Давыдович (13.7.1897, Екатеринослав губ., Никополь ш. — 28.1.1962, Казан), актёр, театр эшлеклесе, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1952). Мариуполь шәһәр уч-щесен (1911), Ростов-Дон шәһәрендәге Дон филармониясенең драма классын (1918) тәмамлый. 1918–26 елларда Мариуполь, Екатеринослав, Новороссийск, Ростов-Дон, Минск, Мәскәү шәһәрләре театрларында актёр була. 1926–32 дә «Кызыл факел» («Красный факел») күчмә театрының җаваплы җитәкчесе (1930–31 дә театрның Р. җитәкчелегендәге труппасы Казанда эшли), 1932–34 тә — К.Маркс исем. Саратов драма театры, 1934–62 дә Казан Зур драма театры директоры. Актёрлык мәктәбен үткән һәм Россиянең күп кенә шәһәрләрендә театр эшенең оештырылу дәрәҗәсе б-н танышу мөмкинлегенә ия булган Р. туплаган тәҗрибәсеннән Казанда эшләү дәверендә иҗади файдалана, иң яхшы театр директорларының берсенә әверелә. Үз эшен труппа оештырудан башлап, күп кенә күренекле сәхнә осталарын туплый. Бөек Ватан сугышы елларында Р. инициативасы б-н театр актёрлары һәм хезмәткәрләре арасында самолёт төзү өчен акча җыю эше оештырыла, хәрби шефлык эше киң җәелдерелә; 1943 тә ул, яшь кадрлар алу хисабына, театр каршында студия эшчәнлеген торгыза; гастрольләр оештыруга күп вакытын сарыф итә. Театрның 1957 дә Мәскәүдә узган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә чыгыш ясавы аңа илнең иң яхшы сәнгать коллективларыннан берсе дигән дан китерә. Сәхнә иҗатының сәнгати ягына зур өстенлек биргән хәлдә, Р. театрның техник ягын оештыруга да җитди игътибар юнәлтә. 1935–36 да Казан Зур драма театрының сәхнә тартмасын үзгәртеп төзи һәм техник яктан җиһазландыра, декорацияләр һәм костюмнар әзерләү остаханәләре оештыра, актёрларның грим салу бүлмәләрен булдыру һәм репетицияләр уздыру өчен биналарны шактый гына киңәйтә. Ул ш.у. актёрларның тормыш-көнкүрешен яхшырту турында да кайгыртучанлык күрсәтә, 1935 тә аның инициативасы б-н элекке «Гранд-отель» кунакханәсе театр хезмәткәрләре өчен тулай торак буларак яңадан җиһазландырыла, 1950–52 дә театр эшләп таптан акчага актёрлар өчен күпфатирлы йорт төзелә. Театрны тамашачыга якынайту өчен Р. тарафыннан төрле чаралар күрелә: театрда ел саен тамашачылар конференцияләре уздырыла, шәһәр һәм респ-ка пр-тиеләрендә актёрларның иҗади отчётлары һәм очрашулары оештырыла. Р. бернечә тапкыр шәһәр Халык депутатлары Советы составына сайлана. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт Билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Г.Д. Ригорин.

*Әд.:* А н т о н о в С. Его имени нет на афише // Театр. 1962. № 4; И л я л о в а И., И н г в а р И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**РИЗАТДИ́НОВ** Рәфкать Габдрахман улы (24.8.1929, Чаллы кантоны, хәзер Сарман р-ны Сөлек а.), генерал-лейтенант (1977). Танк уч-щесен (1950), Бронетанк гаскәрләре хәрби академиясен (Мәскәү, 1963), Генштаб



Р.Г. Ризатдинов.

хәрби академиясен (Мәскәү, 1971) тәмамлый. 1975 елдан Төньяк гаскәрләре төркеменең командующие урынбасары, 1980 нән Карпат буе хәрби округында. 1984–88 дә СССР Кораллы көчләренең Көньяк-Көнбатыш юнәлеше гаскәрләренең башкомандующие урынбасары. 1988 нең июленнән запаста, Львов шәһәрендә (Украина Респ-касы) яши. Орденнар һәм медальләр б-н бүләкләнә.

**РИЗВА́НОВ** Альберт Анатольевич (17.12.1974, Казан), генетик, биол. фән. д-ры (2011). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1995), Невада штаты ун-тында (2006 га кадәр, Рино ш., АКШ). 2006 елдан Казан ун-тында: генетика каф. мөдире (2012 дән), бер үк вакытта фундаменталь медицина һәм биол. ин-ты директоры урынбасары (2012 дән). Хезмәтләре кеше һәм хайван авыруларының ген һәм күзәнәк терапиясенә карый. Организмга рекомбинантлы нуклеин к-талар кертүнең вируслы һәм вируслы булмаган алымнарын эшли. ТР хөкүмәтенең яшь галимнәргә дәүләт ярдәме бүләге иясе (2009).

**РИЗВА́НОВ** Гаяз Гобәйдулла улы (1904, Вятка губ., Сарапул өязе Исәнбай а. — 5.10.1939, Владимир ш.), журналист. 1921–22 елларда Төмән шәһәре пед. техникумында, 1922 дә Казан совет партия мәктәбендә укый. Татар коммунистик ун-тын тәмамлаганнан соң (1925), шунда ук эшли; 1930 дан проректор (бүленеп: 1929–30 да Казан ун-тының юридик ф-ты деканы). 1932 нең февраленнән 1937 нең июленә кадәр «*Кызыл Татарстан*» г-тасының җаваплы сәркәтибе. ТАССРның иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышы проблемалары буенча күпсанлы мәкаләләр бастыра. 1932–34 тә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты пленумнары әгъзасы. 1937 нең 4 апрелендә милли террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булуда гаепләнеп, ун елга ирегеннән мәхрүм ителә; Владимир шәһәрендә тоткынлыкта үлә. 1957 дә аклана.

*Әд.:* Книга памяти жертв политических репрессий. К., 2004. Т. 12; Муслимов А. Хагын да, нахагын да // Социалистик Татарстан. 1988. 18 дек.

*Н.Г.Ризванов.*

**РИЗВА́НОВ** Нәүфәл Гаяз улы (15.1.1930, Казан), астроном, физика-матем. фән. д-ры (1987), проф. (2001). 1954 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казахстан ССРның Астрофизика ин-тында эшли (1955–58). 1958 дән Казан ун-тының В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясендә, 1977–83 тә Ай бүлеге мөдире, 1983–92 дә директор урынбасары. Хезмәтләре селенодезиягә һәм Ай динамикасына, фотографик астрономиягә, эфемерид астрономиягә һәм астрономик приборлар төзүгә карый. Р. беренче булып Ай һәм йолдызларның зур масштаблы сурәтләрен ала, һәм шулар нигезендә Ай кратерларының селенодезик урнашулары каталогы һәм Ай фигурасының моделе төзелә. Нахичевань (1969) һәм Зеленчук (1970) тау астрономик станцияләрен оештыра. Галлея кометасының, Марс иярченнәренең күп кенә фотографик күзәтүләрен эшли. Р. җитәкчелегендә берничә телескоп төзелә. Халыкара астрономия берлеге (1981 дән), Европа (1995 тән) һәм Россия (1995 тән) астрономия җәмгыятьләре әгъзасы. Актив галактикалар төшләрен, гаммакабынышларны, космик рентген чыганакларын, астероидларны һәм йолдызларның нечкә спектроскопиясен тикшерү буенча хезмәтләре өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2009).

Х е з м.: Система координат опорных кратеров на луне // Тр. Казан. гор. астрон. обсерватории. 1985. № 49; Фотографическая астрономия. К., 1991; Основные концепции ПЗС и фотографической астрометрии. К., 2005 (автордаш).

**РИЗВА́НОВ** Рәшит Әхмәй улы (12.12.1932, БАССРның Миякә р-ны Байтимер а.), геофизик, геол.-минерал. фән. д-ры (1982), проф. (1985). Мәскәү нефть ин-тын (1956), Мәскәү ун-тының механика-матем. ф-тын (1957) тәмамлый. 1959 елдан Мәскәү геол. һәм янучан файдалы казылмаларны эшкәртү ин-тында, 1965 тән Бөтенсоюз төш геофизикасы һәм геохимиясе фәнни-тикшеренү ин-тында, бер үк вакытта Мәскәү нефть һәм газ ин-тында укыта. 1990 нан РФАнең Нефть һәм газ проблемалары ин-тында әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, 2001 дән «Пангея» АҖнең баш белгече. Хезмәтләре нефть һәм газ чыганакларын эзләү һәм эшкәртүнең геофизик алымнарына карый. Р. тау токымнарының составын һәм үзлекләрен өйрәнүдә төш-физика алымын эшли, скважиналарны тикшерүнең геофизик алымнарын комплекслы куллануны тәкъдим итә. Уйлап табуга 30 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**РИНА́Т**, Әлмәт мәчете, к. *Әлмәт мөселман дини мәгърифәт үзәге*.

**РИСАЛӘ́** (гарәп. رسالة — юллама, хат, трактат) урта гасырлар гарәп, фарсы, төрки әдәбиятлары жанры. 8 йөздә гарәпләрдә кыска хат, сәяси яисә фәлсәфи эчтәлекле трактат буларак формалаша. Төрки-татар әдәбиятында Р. жанрындагы әсәрләрдән Ялчыголның «Рисаләи Газизә»сен мисал итеп китерергә мөмкин. 19 йөз – 20 йөз башы татар әдәбиятында тезмә һәм чәчмә формада язылган, күпчелек очракта кечерәк күләмле гыйльми, популяр, публицистик язмаларга карата кулланыла. Хәзерге заманда сирәк кулланыла.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

**РИФЕ́Й**, р и ф е й э о н о т е м а с ы (лат. Ripheus — Урал тавы атамасыннан), бөтендөнья стратиграфик шкалада соңгы *кембрийгача чорга* (югары протерозой) караучы иң зур бүлекчә. Геол. яше 1650±50–650±20 млн. ел. Түбән протерозойдан соң, *венд* алдыннан килә. Геолог Н.С.Шатский б-н берлектә 1945 елда билгеләнә. Татарстан терр-ясендә Р. 1946 дан 1960 еллар уртасына кадәр түбән Баулы ассериясе (к. *Баулы сериясе*) дип йөртелә. Р. 3 эратемага бүленә: түбән (1350±50 млн. ел югары чик), урта (1000±50 млн. ел) һәм югары (650±20 млн. ел). Түбән һәм югары Р. утырмалары ТРның көньяк-көнчыгышында 1500 *м* дан артыграк тирәнлектә ачыкланган, урта Р. төньяк-көнчыгышта — *авлакогеннарда* — тар бөгелешләрдә туплана. Р. токымнары комсу-балчык катламнан кремнийлашкан доломит, мергель, гравелитлардан тора. Түбән Р.ның якынча калынлыгы 1500 *м*, югарының — 1000 *м*. Утырмалар континенталь, яр буе-диңгез, сай сулы-диңгез һәм диңгез шартларында формалаша. Климат берничә тапкыр корыдан дымлыга кадәр үзгәрә. Р. диңгезләрендә зәңгәрсу-яшел суүсемнәр үсә. ТРның көньяк-көнчыгышында Р. утырмаларында нефть-газ чыганаклары ачыкланган.

*Әд.:* Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003.

*Е.М.Аксёнов.*

**РКП(б) ҮЗӘ́К КОМИТЕТЫ́ КАРШЫНДАГЫ́ ТАТА́Р-БАШКО́РТ ҮЗӘ́К БЮРОСЫ́.** Татарстан һәм Башкортстан АССРлардан читтә эшчәнлек алып барган татар-башкорт секцияләренең эшен координацияләү өчен Бөтенроссия татар-башкорт коммунистларының беренче конференциясе карары б-н 1922 елның мартында Мәскәүдә оештырыла. РКП(б) ҮКның агитация-пропаганда бүлеге карамагында була. Составы әледән-әле үзгәреп тора. Әгъзалары: М.Дәүләтшин, Ш.Ибраһимов, Ш.Измайлов, М.Солтангалиев, М.Таһиров; 1923 тә Бюро составына С.Атнагулов, Ф.Әхмәтов, М.Парсин, Ш.Сакаев һ.б. кертелә. Төп максатлары: милли-буржуаз идеологиягә каршы көрәшү, хезмәт ияләрен мөселман дин әһелләре йогынтысыннан арындыру, пролетар интернационализм рухында тәрбияләү, татарлар б-н башкортларны Коммунистлар партиясе һәм Совет хакимияте тирәсенә туплау. Үзәк Бюро татар һәм башкорт хезмәт ияләре арасында эшләү өчен милли кадрлар әзерли, туган телдә марксизм-ленинизм рухында сәяси аңлату эшләре алып бара; партия куйган бурычлардан чыгып, өлкә, губерна, өяз татар-башкорт бюро һәм секцияләре эшенә җитәкчелек итә; Мәгариф халык комис-ты һәм Һөнәри белем бирү баш идарәсенең аз санлы халыклар Советы татар-башкорт бюросы эшчәнлегенә юнәлеш бирә; Татарстан һәм Башкортстаннан читтә яшәүче татар һәм башкортлар арасында халык мәгарифен һәм мәдәни-агарту эшләрен камилләштерү буенча РКП(б) ҮКна тәкъдимнәр кертә. «*Эшче*», «*Игенчеләр*», «Кызыл дәфтәр» г-таларын нәшер итә. 1930 да эшчәнлеге туктатыла.

*Әд.:* Первая Всероссийская конференция коммунистов татаро-башкир, не вошедших в автономные республики тюркских народов. М., 1922; Ш а ф и г у л л и н Н. Татаро-башкирские секции партийных комитетов в восстановительный период (1921–1926 гг.): Дис.... К., 1972.

**РКП(б) ҮКның ДҮРТЕНЧЕ́ КИҢӘШМӘСЕ́.** Милли респ-калар һәм өлкәләрнең җаваплы хезмәткәрләре катнашында 1923 елның 9–12 июнендә Мәскәүдә уздырыла. РСФСР милләтләр эшләре буенча халык комиссары И.В.Сталин тәкъдиме һәм РКП(б) ҮК Политбюросы әгъзалары Г.Е.Зиновьев һәм Л.Б.Каменев хуплавы б-н советлар берлеге дәүләте төзү чорында «милли башбаштаклыкка» каршы көрәш чараларын билгеләү

максатыннан чакырыла. Киңәшмә эшендә РКП(б) ҮК әгъзалары һәм әгъзалыкка кандидатлардан (Г.Е.Зиновьев, М.И.Калинин, Л.Б.Каменев, С.М.Киров, В.В.Куйбышев, Д.З.Мануильский, Н.Нариманов, Г.К.Орджоникидзе, Н.А.Скрыпник, И.В.Сталин, Л.Д.Троцкий, М.В.Фрунзе һ.б.) тыш, милли респ-калар һәм өлкәләрдән 58 вәкил: К.Г.Мохтаров, Г.М.Енбаев (Татарстан АССР); Б.Н.Нимвицкий, М.Д.Халиков (Башкортстан АССР); С.С.Сәетгалиев, И.К.Фирдәүс (Кырым АССР); Т.Р.Рыскулов (Төркестан АССР) һ.б. катнаша. Көн тәртибенә төп мәсьәлә итеп И.В.Сталинның «Партиянең XII съездында кабул ителгән милли мәсьәләгә кагылышлы резолюцияне тормышка ашыру буенча гамәли чаралар» доклады куела. Урыннардагы вазгыять турындагы докладлар б-н 20 милли респ-ка һәм өлкә вәкилләре чыгыш ясый. Киңәшмәдә ш.у. РКП(б) Үзәк контроль комиссиясе рәисе В.В.Куйбышевның М.Х.Солтангалиевне партиягә һәм Совет дәүләтенә каршы эшчәнлектә гаепләгән доклады тыңлана. «Солтангалиев эше» Бөтенроссия гадәттән тыш комиссиясе тарафыннан И.В.Сталин күрсәтмәсе буенча оештырыла. «Милли сәясәтнең либеральләшүеннән» файдаланып, РКП(б)ның 12 нче съезды кабул иткән милли мәсьәләләргә кагылышлы карарларны халыкка җиткерергә һәм шуның б-н «бөек держава» тарафдарлары һәм «бөек рус» шовинистларының милли респ-каларны, аеруча мөселман халыклары яши торган автономияле берәмлекләрне кысрыклавын чикләргә омтылучы урынбасары М.Х.Солтангалиевнең гамәлләре И.В.Сталинда кискен канәгатьсезлек тудыра. В.В.Куйбышев һәм съездда докладтан соң фикер алышуларда катнашкан күпләр (И.В.Сталин, С.С.Сәетгалиев һ.б.) Солтангалиевне партия үзәк органнары үткәрә торган чараларга каршылык күрсәтү максатыннан яшерен милли оешма төзүдә, башкорт лидеры Ә.Вәлиди һәм кайбер шәрекъ илләрендәге (Иран, Төркия һ.б.) фикердәшләре б-н элемтә урнаштырырга, аларны совет хакимиятенең милли мәсьәләне хәл итүгә кагылышлы сәясәтенә каршы котыртырга омтылуда гаеплиләр. Киңәшмә әгъзалары Солтангалиевне партиядән чыгару һәм барлык вазифаларыннан азат итүнең дөрес гамәл булуын раслыйлар (шул ук вакытта ул ирektә калдырыла). Киңәшмәдә кабул ителгән милли мәсьәләгә кагылышлы карарлар чынлыкта РКП(б)ның 12 нче съездында Совет Россиясе халыкларына бирелгән «ирекләр хартиясе»н юкка чыгара, И.В.Сталинга һәм аның фикердәшләренә, «сул» һәм «уң» тайпылышларга каршы көрәшне сәбәп итеп, совет респ-каларындагы милли кадрларны сәяси әзәрлекләүгә шартлар тудыра (к. *Солтангалиевчелек*), СССРда милли-дәүләт төзелешенең сталинчыл концепциясе җиңеп чыгуга китерә.

Чыг.: ВКП(б) в резолюциях и решениях съездов, конференций и пленумов ЦК. М., 1941. Ч. 1; Тайны национальной политики ЦК РКП(б): Стенографический отчёт секретариата IV совещания ЦК РКП(б), 1923 г. М., 1992; Стенографический отчёт совещания членов Татобкома и ОКК совместно с ответственными работниками по национальному вопросу // Татарстан. 1993. № 2–3, 6–8.

**РКП(б)ның КӨНЧЫГЫ́Ш ФРОНТТАГЫ́ ТАТА́Р-БАШКО́РТ ҮЗӘ́К БЮРОСЫ́.** Көнчыгыш фронттагы коммунист мөселманнар конференциясе (Сызрань ш.) карары б-н 1919 елның апрелендә оештырыла. Рәисе — Г.С.*Баембәтов*. Программасы: РКП(б) ҮКның барлык карарларын тормышка ашыру, контррев-ция каршылыгын тиз арада бастыру максатыннан Кызыл Армия составындагы мөселман гаскәре берәмлекләренең сәяси-сыйнфый аң-белем, хәрби әзерлек дәрәҗәсен күтәрү, Көнчыгыш фронт күләмендә әдәби-нәширлек эшен, мәдәни-агарту эшчәнлеген үзәкләштерү. Бюро 1919 ның августына кадәр эшли.

**РКП(б)ның МӨСЕЛМА́Н ОЕШМАЛАРЫ́ ҮЗӘ́К БЮРОСЫ́.** *Мөселман коммунистларның беренче бөтенроссия съезды* карары б-н Мәскәүдә 1918 елның ноябрендә оештырыла. Максаты — РКП(б)ның урындагы ком-тларында мөселман секцияләре һәм бюролары эшен координацияләү. Рәисе — И.В.Сталин, әгъзалары: Б.Сәрдәров (рәис урынбасары), Г.Ялымов (рәис урынбасары), М.Х.Солтангалиев, Х.Й.Ямагулов (сәркәтип), К.Л.Якубов (казначы); әгъзалыкка кандидатлар: Д.Х.Буниатзадә, М.Г.Дулат-Али, М.Конов, И.Ш.Рәхмәтуллин, Н.Я.Яруллин. Үзәк бюрода татар, башкорт, кыргыз, әзәрбайҗан, Төркестан, тау халыклары һ.б. секцияләр; җирле халык һәм мөселман кызылармиячеләр арасында пропаганда эше алып бару өчен эре милли төбәкләр (Идел буе, Кавказ, Төркестан) буенча аерым бүлекчәләре булдырыла. РСФСР терр-ясендә яшәүче мөселман хезмәт ияләре һәм РСФСР б-н чиктәш Шәрекъ илләрендәге эмигрант коммунистик төркемнәре арасында эш алып баручы халыкара пропаганда бүлеге (җитәкчесе М.Сөбхи) РСФСРның Милләтләр эше буенча халык комис-ты Үзәк мөселман комис-тыннан ҮБ карамагына күчерелә. ҮБ агитация-пропаганда һәм нәшрият эшчәнлеге алып бара, мөселман коммунистларны Кызыл Армия сафларына мобилизацияли. 1919 ның мартына 10 меңгә якын мөселман коммунистны берләштерә. «*Эшче*» г-тасын нәшер итә. 1919 ның марты башында РКП(б)ның җирле ком-тлары каршында күп кенә шәрекъ халыклары коммунистларының секция һәм бюролары төзелә; шуңа бәйле рәвештә, РКП(б) ҮК ҮБны *Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк Бюросы* дип үзгәртү турында карар кабул итә.

*Әд.:* Гражданская война и военная интервенция в СССР: Энцикл. М., 1987; Х а й р у т д и н о в Р.Г. Трудное возрождение. К., 1992.

**РКПның ЧИТ ИЛ ВӘКИЛЛӘРЕ́ СЕ́КЦИЯЛӘРЕ**, к. *Казанда чит ил коммунистлары шөгъбәсе*.

**РОБАГЫ́Й** (гарәп. رباعي — дүртләтелгән), Шәрекъ халыклары шигъриятендә лирик жанр; ааба, аерым очракларда аааа рәвешендә рифмалаша торган, тәмамланган дүртьюллык. Аерым очракларда *рәдиф* кулланыла. Лирик кичерешләр, фәлсәфи уйлануларны белдерүгә хезмәт итә. Тарихы фарсы фольклорына барып тоташа. Язма рәвештә 9–10 йөзләрдән билгеле, ш.и. борынгы төрки язма әдәбиятында да. Р. остасы булып фарсы шагыйре һәм галиме Гомәр Хәйям санала. Татар әдәбиятында Р. жанрына Сәйф Сараи, Акмулла, Г.Тукай, М.Гафури, Дәрдемәнд, Ш.Бабич, Х.Туфан, Ә.Исхак, Н.Арсланов, З.Мансур, Р.Гатауллин һ.б. мөрәҗәгать итә.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

**РОГАЧЁВ** Дмитрий Дмитриевич (20.9.1895, хәзер Калуга өлкәсенең Жуковский р-ны Зур Росляковка а. — 1.6.1963, Яшел Үзән ш.), контр-адмирал (1941). М.В.Фрунзе исем. Хәрби-диңгез уч-щесен тәмамлый (Мәскәү, 1929). 1915 елда хезмәтен Балтыйк флотында «Слава» линкорында рулевой булып башлый. Окт. рев-циясе чорында Гардемарин классларды казармасын, Таврия сарае сакчыларын, Нева елгасы аша салынган күперне алуда, Гатчина янындагы һәм Царское Село (хәзер Пушкин ш.) р-ныдагы сугышларда, Гражданнар сугышында катнаша, Байкал күле янындагы Себер хәрби флотилиясе отряды башлыгы ярдәмчесе булып хезмәт итә. Көнчыгыш фронтның элемтә хезмәте башлыгы (1920). 1921 дән монитор командиры, аннары дивизион һәм мониторлар бригадасы командиры һәм комиссары, 1938 нең маеннан Амур флотилиясе командующие урынбасары. 1940 тан Пинск, 1942 нең февраленнән Идел буе хәрби флотилиясе командующие, 1943 нең июленнән Хәрби-диңгез флоты корабльләре отряды б-н командалык итә, 1944–46 да Днепр флотилиясендә Киев хәрби-диңгез базасы командиры. Бөек Ватан сугышында Р. җитәкчелегендәге Идел буе флотилиясе Сталинград оборонасында мөһим роль уйный. Сугыштан соң өйрәнү отрядында, аннары отрядта һәм корабльләр төзү бригадасында командир вазифасында була. 1956 дан запаста. Ике Ленин ордены, өч Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*М.З.Хәбибуллин.*

**РО́ГОВА** Татьяна Владимировна (10.10.1949, Казан), эколог, биол. фән. д-ры (2001), проф. (2002), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2004). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1971). Казан ун-тында эшли, гомумэкология каф. мөдире (2003 тән). Хезмәтләре фәзаи структураның һәм зона экотоны шартларында фитотөрлелек динамикасының экологик закончалыкларына карый. Р. РФдә экологик белем бирү системасын эшләүдә катнаша, «Идел-Урал экология челтәре» составында Татарстанның экология челтәрен оештыру, РФдә биотөрлелекне саклау эшләре буенча координатор. ТР флорасы кадастрын инвентаризацияләү һәм эшләү буенча фәнни җитәкче. ТРның Кызыл китабын (1995, 2006) һәм ТРның аеруча саклаулы табигать терр-яләре дәүләт реестрын (1998, 2007) төзүдә катнаша. Үсемлекләр дөньясын тикшерүчеләр халыкара ассоциациясе әгъзасы (1998 дән). Мәгариф өлкәсендә РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты (2000). СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Экология и охрана природы: В 2 ч. К., 1988; Сосудистые растения Республики Татарстан.

К., 2000 (автордаш); Вероятностная модель формирования флористического состава растительных сообществ // Ботанический журн. 2005. Т. 90. № 3 (автордаш); Атлас сосудистых растений Татарстана. К., 2008 (автордаш).

**РОГО́ЖИН** Виктор Иванович (22.10.1927, Самара ш.), сынчы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1996). Куйбышев һөнәри-сәнгать уч-щесен (1948), Баку сәнгать уч-щесен (1954), СССР САнең И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын тәмамлый (1960, М.К.Аникушин остаханәсе). 1960 елдан — Казанда, Казан сәнгать уч-щесендә укыта (1973–74), 1970–80 елларда ТР сәнгать фондында эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1976). Станлы һәм монументаль скульптура өлкәсендә әйдәп баручы осталарның берсе, героик-тарихи портрет жанрында эшли («Эшче», 1961; «С.Сәйдәшев», 1961–73, Р.*Нигъмәтуллина* б-н автордаш; «Крестьян мәсьәләсе», 1963; «Муса Җәлил», 1973, 1975; «Ленин», 1973; «Антон Петров», 1975; «С.Рахманинов», 1978; «Ф.Шаляпин», 1979; «Рәссам И.Шишкин», 1979; «Ф.Э.Дзержинский», 1985). Казандагы һәйкәлләр һәм бюстлар: Г.Камал (1959), Г.Ибраһимов (1968), А.В.Вишневский (1969), М.Вахитов (1979), Н.Г.Рахлин (1985), Дәрвишләр бистәсендәге «Беренче юл яручыларга» (1989); ТРның шәһәр һәм авылларында: Антоновка авылында — А.Петров (1986), Күн авылында — Советлар Союзы герое П.М.Гаврилов (1980), Лениногорск шәһәрендә — В.Н.Шашин (1983), Алабуга шәһәрендә — И.И.Шишкин (1991), Болгар шәһәрендә — И.А.Нагаев (1991) һәм Г.А.Шаронов (2005); Актаныш авылында (1967–68), Болгар шәһәрендә (1990), Лениногорск шәһәрендә (1998–2002) «Батырлар аллеялары»; хатыны Р.Нигъмәтуллина һәм кызлары И.Рогожина һәм М.Нигъмәтуллина б-н берлектә Казанда С.Сәйдәшев исем. Зур концерт залы өчен композиторларның бюстлары һәм барельефлары сериясе (1995) авторы. Мәрмәр, гранит, бронза, чүкеп ясалган бакыр, агач һәм гипс б-н эшли. Әсәрләре монументальлеге һәм образларның җанлылыгы, сәнгати сурәтнең төгәл һәм аңлаешлы булуы б-н аерылып тора.



В.И.Р о г о ж и н. «Әни». Агач. 1965.



В.И.Р о г о ж и н. СССРның халык артисты Фоат Халитов. Тоныкландырылган гипс. 1978.

Респ-ка (1960 тан); төбәк («Зур Идел», 1964, 1974, 1980); бөтенроссия (Бөек Җиңүнең 30 еллыгына, Волгоград, 1975) күргәзмәләрендә катнаша. Беренче төркемле гаилә күргәзмәсе 1994 тә Казанда уздырыла. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, А.М.Горькийның Казандагы әдәби-мемориаль музеенда, Ленино-Кокушкино авылындагы Ленин музей-йортында, Алабуга шәһәрендә И.И.Шишкин музей-йортында, Әлмәттәге картиналар галереясында, Әстерхандагы Б.М.Кустодиев исем. картиналар галереясында һ.б. саклана.

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Хисамова Д.Д. Рада Нигматуллина. К., 2005.

**«РО́ДИНА»**, Алексеев р-ындагы колхоз. 1956 елда «Татарстанның 30 еллыгы» к-зын бүлү нәтиҗәсендә оештырыла. 1961 дә хуҗалыкка «Искра» к-зы кушыла. Үзәк утары — Юеш Көрнәле авылы. А.х. файдалану җирләренең мәйданы 4520 *га*, ш.и. сөрүлек җирләр 4165 *га*. Эшләүчеләр саны 205 кеше. Төп юнәлеше — бөртекле ашлык, сөт, ит җитештерү. 2014 тә хуҗалыкта 2406 баш мөгезле эре терлек (ш.и. 625 сыер), 802 баш дуңгыз исәпләнә. 100 *га* сөрүлек җирләргә күчереп исәпләгәндә 7152 *ц* бөртекле ашлык, 100 *га* а.х. файдалану җирләренә — 391,5 мең *ц* сөт, 36,6 мең *ц* ит җитештерелә. Җитештерүдәге табышлылык дәрәҗәсе 31% тәшкил итә. Хуҗалык берничә тапкыр (1970–71, 1974–77, 1981–82, 1985–86) КПСС ҮКның, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. Хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены — 5 кешегә, «Почёт билгесе» — 2, 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны — 1, медальләр 2 кешегә бирелә.

Хуҗалыкның җитәкчеләре: И.П.Емельянов (1956–68), М.М.*Самородинов* (1968–72), К.М.*Сафин* (1972–2003), И.М.Әхмәтов (2003 тән).

**РОДИО́НОВ** Александр Миронович (22.2.1918, Казан губ., Чистай өязе Берёзовка а. — 19.2.1995, Казан), нәкышьче, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1975), ТАССРның халык рәссамы (1978), РСФСРның атказ. рәссамы (1981). Ташкент сәнгать уч-щесен тәмамлый (1938). 1938 елдан — Казанда, «Татхудожник»та эшли («Телеңне тый» плакаты авторы, 1941). 1941–46 да Кызыл Армиядә, Бөек Ватан сугышында катнаша, армия газетасында эшли. 1946–48 дә Казан сәнгать уч-щесендә укыта. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1960). 1953–80 дә ТАССРның Сәнгать фондында.

Р. башка жанрларда күп һәм актив иҗат итсә дә, аның иҗатында хәрби тема өстенлек итә. Элгәреге әсәрләрендә фашистлар оккупациясе темасы урын ала: «Коллыкка» (1947), «Фашистлар төрмәсендә» (1950 еллар). 1950 еллар ахырыннан рәссамның әсәрләренә лиризм хас: «Ялда. Солдат язы» (1959), «Тормыш көче» (1965), «Икмәк» (1972–74). Шагыйрьнең Волхов фронтындагы землянкада сурәтләнүе «Җәлил» картинасын (1973–75) тагын да чынрак һәм киеренкерәк итә. Рәссамның иҗатында портрет жанрына яки катлаулы, күп фигуралы композицияләргә якын торган тарихи картиналар зур урын били: «Фёдор Шаляпин» (1957), «Себер тракты» (1959), «Сергей Есенин» (1964), «Ага Базар», «Болгарлар. 1722 (Пётр I)», «Болгарлар» (1981) триптихы, «Профессор А.П.Щапов» (1982). Портретларга модель б-н төгәл охшашлыкка һәм образларны психол. ачуга омтылу хас: «Кыз портреты» (1947), «Ат үрчетүчеләр» (Татар ат з-ды алдынгылары портретлары, 1978–79), «Советлар Союзы Герое С.С.Садриев портреты» (1982). Р.ның масштаблы пейзажлары 1960–70 еллардагы хезмәт җиңүләренең бөеклеген һәм киңлеген ачып бирә: «Туган җир» (1967), «КамГЭС иртәсе» (1976). «Күпер» (1956), «Март» (1958), «Саф җил» (1961), «Яз җитә» (1964), «Камада. Саескан таулары» (1972–74), «Көз фасылы» (1973) һ.б. табигать күренешләре сериясенә шигъри аһәңнәр һәм лиризм хас.



А.М.Родионов.



А.М.Р о д и о н о в. «Фёдор Шаляпин». 1957. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.



А.М.Р о д и о н о в. «Кайту». 1985. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.



П.З. Родионов.

Респ-ка (1942 дән), РСФСР рәссамнары әсәрләре (1955, 1957), «Советская Россия» (1960), «РСФСРның 16 автономияле республикасы» (1971), төбәк («Зур Идел», 1964, 1967, 1974, 1980, 1991) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда уздырыла (1968, 1983, 2008). Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Болгар тарих-архит-ра музей-тыюлыгында, А.М.Горькийның Казандагы әдәби-мемориаль музеенда, Әлмәттәге картиналар галереясында, шәхси тупланмаларда саклана. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Я х л и е л ь Б. Александр Родионов: Буклет. К., 1976; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*М.Е.Ильина.*

**РОДИО́НОВ** Пётр Зиновьевич (26.4.1923, Буа кантоны Кадыш а. — 26.6.1978, Казакъстан ССР, Тургай өлкәсенең Амантогай р-ны Тасты а.), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), гв. сержанты. Туган авылында колхозда эшли. 1942 елдан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 254 нче миномёт полкында батарея өлкән разведчигы (5 нче гв. артиллерия һөҗүм дивизиясенең 27 нче миномёт бригадасы). 2 нче Украина фронты гаскәрләре составында Дебрецен (1944) һәм Будапешт (1944–45) операцияләрендә катнаша. Тиса елгасын кичеп, Эллеш (Венгрия) авылы янында батырлык күрсәтә: 1944 нең 9 октябрь төнендә каршы беренче булып рация б-н елга аша бүрәнәдә йөзеп чыга, шуышып килеп, дошманның беренче траншеясына граната ташлый. Сугыш дәвамында дошманның ут ноктаЛарын билгеләп, координаталарын тапшыра, миномётчылар утына төзәтмә кертеп, укчы подразделениеләренең елга аша чыгуын тәэмин итә. 1946 да Совет Армиясеннән демобилизацияләнә. Тасты авылының бер урамы Герой исемен йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**РОДИО́НОВА** Анна Николаевна (1751, Калуга губ. — 30.12.1827, Казан), Казан алпавыты. Әтисе үлгәннән соң, бөлгенлеккә төшеп, абзасы, Казан алпавыты В.Тенишев гаиләсендә тәрбияләнә. 18 яшендә полковник И.А.Родионовка кияүгә чыга, 1774 елда Е.И.Пугачёв гаскәрләре Казанны алганда ире һәлак була. Иренең дусты, Казан һәм Зөя митрополиты Вениамин киңәше б-н, аның әҗәткә биргән акчасына, балык тоту урыннары, печәнлек җирләр һәм тегермәннәр сатып ала. Тора-бара Казан губернасындагы барлык балык тоту урыннарына хуҗа була; Казан, Мәскәү, С.-Петербургта балык сата. Ашлык б-н сәүдә итә башлый, казнага сата. Эре җирбиләүчегә әверелә: Казан, Сембер губерналарында Александровка, Арышхазда, Кыят, Түбән Дәүләтъяр, Обуховка, Тәңгәче, Шайтан һ.б. авылларны җирләре б-н сатып ала. 1820 еллар башына утарларын варисларЫ арасында бүлә, балачагы ятимлектә һәм ярлылыкта үткән Р. үз өлешен (283 мең сум), Казанда дворяннар нәселеннән булган кыз балалар тәрбияләүче уку йорты ачу һәм тотуга мирас итеп калдыра. Р. үлгәннән соң, аның оныгы Л.П.Родионов б-н мирас мәсьәләсендә низаг килеп чыгу сәбәпле (ул 1837 дә оештырылачак институт файдасына хәл ителә), васыять үтәлмичә кала. Уку йорты аның оештыручысы исемен йөртә башлый — *Родионованың затлы нәсел кыз балалар институты.*

*Әд.:* С п а с с к и й Н.А. Празднование юбилея Казанского Родионовского института благородных девиц. 1841–1891. К., 1891.

*Л.М.Свердлова.*

**РОДИО́НОВАНЫҢ ЗАТЛЫ́ НӘСЕ́Л КЫЗ БАЛАЛА́Р ИНСТИТУТЫ́**, Казанда, урта гомуми уку йорты. Уставы 1838 елда раслана, 1841 дә институт ачыла. Дворян кызлары өчен ябык уку йорты була, С.-Петербургтагы Смольный ин-ты үрнәгендә эшли. Алпавыт хатын А.Н.*Родионованың* мирас итеп калдырган акчасына ачыла һәм тотыла. Институтның башында Казан губернасының дворяннар җыелышы билгеләгән попечительләр ком-ты тора (тол дворян хатыннар гына җитәкчелек итә), укыту эшчәнлеге өчен инспектор җавап бирә, гадәттә ул Казан ун-ты профессоры була. Институтка дворян гаиләләреннән башлангыч белемне мәктәптә яисә өйдә алган кызлар кабул ителә. Уку срогы 6 елдан 8 елга кадәр, 1911 дән — 10 ел; ел саен ин-тны 40 кыз тәмамлый. Уку өчен түләү югары була, ләкин укучыларның шактый өлеше ин-т хисабына яисә дворяннар җыелышы билгеләгән стипендиягә укый. Институтта ныклы дисциплина һәм чикләүләр (укучыларны өйләренә каникулга гына җибәрәләр, ата-аналар алар б-н укытучылары янында гына очраша ала), спартаннарча көнкүреш, рациональ туклану, организмны чыныктыру (теләсә нинди һава шартларында да йөрергә чыгу, биналарда түбән температура һәм җиңелчә киенү) кебек тәрбияви принциплар була. Беренче унъеллыкта укыту программасыз һәм дәреслекләрсез алып барыла, ин-т урта белем бирү дәрәҗәсенә якынча гына туры килә. 1870 тә попечительләр ком-ты карары б-н кыз балалар гимназияләре программасы кертелә, пед. эшчәнлек халык мәгарифе органнары күзәтүе астына куела. Тиздән ин-т Идел буенда кыз балалар өчен иң яхшы уку йортына әверелә, югары дәрәҗәдә белем бирү оештырыла, өлкән сыйныфларда төп фәннәрне Казан ун-ты һәм Казан руханилар академиясе профессорлары укыта. Ин-тны тәмамлаучыларның күбесе башлангыч мәктәп укытучылары булып китә, кыз балалар өчен югары уку йортларына укырга керә. Ин-тта Л.Н.Толстойның кече сеңлесе М.Н.Толстая, В.Н.Фигнер һ.б. укый. 1917 ел ахырында ябыла.



Родионованың затлы нәсел кыз балалар институты. Казан. Архитекторы Ф.И.Петонди. 1838–41. 19 йөз ахыры фоторәсеме.

Институт бинасы — соңгы классицизм стилендәге архит-ра истәлеге (1838–41, арх. Ф.И.Петонди). 1918 дән Казан пед. ин-ты карамагында була, 1944 тән анда Казан Суворов хәрби уч-щесе урнаша.

*Әд.:* Л е п о р и н с к и й И. О жизни и деятельности бывшей начальницы Казанского Родионовского института Сусанны Александровны Мертваго. К., 1879; С п а с с к и й И.А. Празднование юбилея Казанского Родионовского института благородных девиц. 1841–1891. К., 1891; Святой храм во имя Св. Мученицы царицы Александры при Казанском Родионовском институте благородных девиц в Казани на Арском поле (к 75-летию института. 1841–1916 г.). М., 1916.

*Е.В.Липаков.*

**РОДНИКИ́** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 25 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Шонталы елгасы буенда. 2010 елда 163 кеше (мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1699 елга кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында — Шентала по речке Булаку, 1967 гә кадәр Лягушкино исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Христо-Рождество чиркәве (1879 да төзелә), Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе, кредит ширкәте, 1 су һәм 4 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, 1 казна шәраб һәм 4 вак-төякләр кибете була; чәршәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1852,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Полянка волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 155 ир-ат; 1859 да — 871, 1897 дә — 1447, 1908 дә — 1754, 1920 дә — 1658, 1926 да — 1271, 1938 дә — 791, 1949 да — 479, 1958 дә — 537, 1970 тә — 510, 1979 да — 374, 1989 да — 266, 2002 дә — 215 кеше.

**РОДНИ́ЩЕВ** Николай Егорович (2.1.1942, Воронеж өлкәсенең Лиман р-ны Кызыл Лиман а.), очыш динамикасы һәм оптималь идарә өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1998). 1965 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1965–78 елларда Мәскәү авиация техноло-

гиясе һәм җитештерүне оештыру фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында (КФ НИАТ) эшли. 1975 тән Казан техник ун-тының гамәли математика һәм информатика кафедрасында, проф. (1998 дән), каф. мөдире (2002 дән). Хезмәтләре детерминант һәм стохастик процессларны оптимальләштерү теориясенә һәм алымнарына карый. Р. очкыч аппаратларның стенд һәм очыш сынаулары өчен автоматлаштырылган мәгълүмат эшкәртү системаларына (АСОИ) матем. һәм программ ассистемалар эшли (тәҗрибә үрнәкләре КФ НИАТта эшләнә һәм авиация сәнәгате пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә). Р. очраклы ярсынулар була торган (ярсынулар төрле чикләүләр куелган стохастик дифференциаль тигезләмәләр б-н бирелә) нәсызыкча динамик системаларны идентификацияләүнең зарури шартларына билгеләмә бирә һәм өйрәнә (тикшеренү нәтиҗәләре очкыч аппаратлар һәм махсус эшләнмәләрнең авиация пилотажы җайланмаларын сынау системасын эшләгәндә кулланыла).

Х е з м.: Оптимизация терминальных стохастических систем. М., 1987 (автордаш); Необходимые условия оптимальности управления разрывных нелинейных стохастических систем с ограничениями // Изв. РАН. Теория и системы управления. 2001. № 6; Оптимизация управления нелинейных стохастических систем с ограничениями // Автоматика и телемеханика. 2001. № 2.

**РОДНЫ́Х** Михаил Васильевич (5.11.1906, Воронеж ш. — 28.12.1970, Казан), Сов. Союзы Герое (25.3.1943), подполковник. Авиация белгечләре хәрби мәктәбен (1929), авиация техникумын (Ленинград, 1933), Батайск югары очу әзерлеге авиация мәктәбен (1937) тәмамлый. 1928–30 елларда һәм 1941 нең июненнән Кызыл Армия сафларында. Гражданнар һава флоты транспорт отряды командиры була. Сугыш алдыннан Ленинабад аэроузелында эшли. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, Казанда оештырылган 81 нче авиация дивизиясе составына билгеләнә. Ленинград, Мәскәү, Сталинградны саклаганда, Курск дугасында сугышчан очышларда катнаша. 1943 нең 15 февраленә кадәр авыр бомбардировщик б-н дошманның ерак тылына 85 төнге сугышчан очыш ясый. 1943 нең мартында Р. аеруча мөһим хөкүмәт йөкләмәсен үти: икенче пилот сыйфатында Сов. Союзы Герое подполковник Э.К.Пусэп (штурманы — подполковник С.Ф.Ушаков) экипажы составына кертелеп, самолёт б-н совет хөкүмәте делегациясен Англиягә илтү һәм Мәскәүгә алып кайтуда катнаша. Дәүләт сере булган хөкүмәт пакетын Бөекбритания короле Георг VI га тапшыра. 1943 нең җәеннән, күпсанлы очышлар ясап, Берлин, Кёнигсберг, Данцигны бомбага тота. 1943 нең 9 июлендә, сугышчан йөкләмә үтәп кайтканда, самолёты дошман тылында бәреп төшерелә, Р. үзе әсирлеккә эләгә. Концлагерьда 1945 нең 26 апреленә кадәр була, Американың 7 нче армиясе гаскәрләре тарафыннан азат ителә. Дәүләт куркынычсызлыгы органнары тарафыннан тикшерелгәннән соң, 1945 нең сентябрендә иреккә чыгарыла. 890 нчы авиация полкында командир урынбасары булып, аннан соң Орша янында СССР Хәрби-Һава көчләрендә хезмәт итә. 1953 тән запаста. Казан аэропортында очыш б-н җитәкчелек итә. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



М.В. Родных.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

**РО́ДЧЕНКО** Александр Михайлович (23.11.1891, С.-Петербург — 3.12.1956, Мәскәү), нәкышьче, график, фотограф, театр һәм кино рәссамы. СССРда дизайн һәм реклама хезмәтенең башында торучы, конструктивизмга нигез салучыларның берсе. Театр бутафоры гаиләсендә туа. 1902–14 елларда Казанда. Казан сәнгать мәктәбендә Н.И.Фешинда укый (1911–14). 1915 елның 2 нче яртысында Мәскәүгә күчә, Строганов сәнгать-сәнәгать уч-щесендә укый (1915–16). 1916–17 дә армиядә хезмәт итә. Мәскәүдә нәкышьче-рәссамнар профсоюзын оештыруда катнаша (1917). 1918–21 дә РСФСР Халык мәгарифе комис-тының сынлы сәнгать бүлегендә эшли, музей бюросын җитәкли, сәнгать коллегиясе әгъзасы була. 1919 да «Живскульптарх» җәмгыяте (нәкышь-скульптура-архит-ра синтезын эшләү комиссиясе) әгъзасы. 1921–24 тә Сәнгать һәм мәдәният ин-тында, 1920–30 да ВХУТЕМАСта (Югары дәүләт сәнгать-техника остаханәләре) укыта. ЛЕФ һәм РЕФ иҗат төркемнәре эшендә катнаша (1923–30), «ЛЕФ», «Новый ЛЕФ» ж-ллары рәссамы. Хатыны В.Ф.Степанова б-н бергә эшли.

Р. Казан чорында модерн (инглиз рәссамы О.Бёрдсли йогынтысы), символлар шигърияте, япон сәнгате б-н мавыга. Рәссам башлыча графика жанрында иҗат итә. Материаллар һәм техника төрләре — акварель, каләм, темпера, лак, алтын, көмеш б-н эшләп карый («Ресторанда», 1910; «Көндәшләр», 1912; «Кимоно кигән хатын», 1913; «Виньетка», 1913; «Шәрекъ стилендәге пейзаж», 1914 һ.б.); майлы буяу б-н соңрак Чиләбе сәнгать мәктәбенә нигез салган сабакташы Н.А.Русаков портретын ясый (1912). Сабакташлары А.Китаева, Н.Подбельская, Т.Попова, В.Степанованың график портретларын иҗат итә (1913). 1913 тә беренче тапкыр Казан сәнгать мәктәбенең 3 нче даими күргәзмәсендә катнаша, Р. темпераларының берсен атаклы Казан коллекционеры Н.Н.Андреев сатып ала. Р. 1914 тә Казанда үзенең мавыгуларына футуризм һәм предметсызлык б-н йогынты ясаган В.Маяковский, Д.Бурлюк, В.Каменский чыгышларын тыңлый. 1914–15 тә О.Уайльд пьесасы буенча «Герцогиня Падуанская» спектакленә костюм һәм декорация эскизлары ясый (заказчысы билгесез); «бүлмә-рестораны», «шәрекъ» бүлмәләре, футуристик күргәзмә рәвеше бирелгән аерым корылма (Р. аның өчен махсус 20 картина яза) булган шәхси интерьер бизәлешенең проектын эшли; «Сызык-циркуль композицияләре» дип аталучы предметсыз сәнгатькә юл ачкан аклы-каралы графика һәм коллажларының беренче сериясен иҗат итә (алга таба, кинематография алымын кулланып, серияләп эшли). Анда геом. законнары нигезендә барлыкка килгән конструкция б-н эшләү (рейсфедер, циркуль, линейка кулланып күмер, лак, темпера, акварель, бронза, көмеш б-н башкарыла) ак һәм кара төсләрнең үзара нисбәте яки бер-берсен кисеп буялган геом. фигураларның, калейдоскоптагы кебек, кушылып китү яки таралу комбинациясенә нигезләнә (композиция Мәскәүдә «Магазин» күргәзмәсендә күрсәтелә). 1916–21 дә рус сәнгате авангарды хәрәкәтенә актив кушыла. Нәкышь һәм графика б-н бер үк вакытта объектларны һәм мобильләрне фәзаи конструкцияләү б-н шөгыльләнә, полиграфия, реклама өлкәсендә эшли, җиһазлар, интерьерлар, кече формалы архит-ра объектлары, конструктивизм стилендәге плакатлар проектлары авторы. Совет киносын булдыруда, Л.Кулешовның «Журналистика» (1927), Л.Оболенскийның «Альбидум» (1928), С.Комаровның «Миллионнарга ия курчак» (1928)




А.М. Р о д ч е н к о. «В.В.Маяковский портреты». 1924. В.В.Маяковскийның Дәүләт музее. Мәскәү.

һ.б. режиссёрларның фильмнарын куюда рәссам-декоратор буларак катнаша. 1920 еллар башында фотография б-н шөгыльләнә, дуслары һәм якыннарының (В.Маяковский, Л.Брик, Н.Асеев, А.Довженко, С.Третьяков һ.б.) портретларын ясый, дөньяга фототәҗрибәләр остасы булып таныла. «Вечерняя Москва» г-тасында, «30 дней», «Даёшь», «Пионер», «Огонёк», «Радиослушатель» ж-лларында фотохәбәрче булып эшли.

Пермь нәкышь, скульптура һәм архит-ра сөючеләр җәмгыяте оештырган 5 нче картиналар күргәзмәсендә (Пермь, 1914), Казан рәссамнарының күргәзмәләрендә, «Магазин» (Мәскәү, 1916), 10 нчы Дәүләт «Предметсыз иҗат һәм супрематизм» күргәзмәсендә (Мәскәү, 1919), «0,10» күргәзмәсендә (Мәскәү), 1 нче Дәүләт сәнгать һәм фән күргәзмәсендә (Казан, 1920), «5×5=25» (Мәскәү, 1921), «Совет фотографиясе — 10 елда» (Мәскәү, 1927)

күргәзмәләрендә, Халыкара бизәлеш сәнгате һәм нәфис сәнәгать күргәзмәсендә (Париж, 1925; «Китап сәнгате», «Театр», «Урам сәнгате», «Җиһаз ансамбле» бүлекләре буенча көмеш медаль); АКШ, Франция, Испания, Бөекбритания, Чехословакиядәге фотосалоннарда катнаша.



А.М. Р о д ч е н к о. «Чәчәк тоткан кыз». Картон. Темпера. 1915–1916. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Әсәрләре Россиядә (Третьяков галереясында, Мәскәүдәге В.В.Маяковский музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда), Австралиядә (Канберрадагы Милли галереяда, Яңа Көньяк Уэльсның Сидней шәһәрендәге Сәнгать галереясында), Австриядә (Грац шәһәрендәге Яңа галереяда), Германиядә (Кёльн шәһәрендәге Людвиг музеенда), АКШта (Блумингтон шәһәрендәге Индиана




А.М. Р о д ч е н к о. «Китаплар» плакаты. 1924.

ун-ты музеенда, Кембридж шәһәрендәге Гарвард ун-ты музеенда, Кливленд, Лос-Анджелес шәһәрләренең сәнгать музейларында, Нью-Йорк, Сан-Франциско шәһәрләрендәге хәзерге заман сәнгате музейларында, Санта-Фе, Хьюстон шәһәрләрендәге сынлы сәнгать музейларында, Чикаго шәһәрендәге Сәнгать ин-тында), Швейцариядә (Винтер шәһәрендәге фотомузейда) саклана.

Чиләбе картиналар галереясында Р.ның 1915 елда Н.А.Русаков тарафыннан язылган портреты бар.

Х е з м.: Против суммированного портрета за моментальный снимок // Новый ЛЕФ. 1928. № 4; Крупная безграмотность или мелкая гадость? // Новый ЛЕФ. 1928. № 6; Пути современной фотографии // Новый ЛЕФ. 1928. № 9; Предостережение // Новый ЛЕФ. 1928. № 11.

*Әд.:* В о л к о в - Л а н н и т Л. Александр Родченко рисует, фотографирует, спорит. М., 1968; Р о д ч е н к о А.М. Статьи. Воспоминания. Автобиографические записки. Письма. М., 1982; Л а в р е н т ь е в А. Ракурсы Родченко. М., 1992; С т е п а н о в а В. Человек не может жить без чуда: Письма. Поэтические опыты. Записки художницы. М., 1994; А х м е т о в а Д. «... И вещи станут душами» // Казань. 1995. № 5/6; К л ю ч е в с к а я Е.П. «Мы создавали новое понятие о красоте...» // Татарстан. 1995. № 11/12; Опыты для будущего: Дневники. Статьи. Письма. Записки. М., 1996; Г а л е е в Б.М. Казань глазами Александра Родченко // Казань. 2000. № 1; Александр Родченко. Фотография — искусство. М., 2006; Как Александр Родченко прославил русский фотоавангард на весь мир / Итоги. 2006. № 45.


*Д.И.Әхмәтова.*

**РОДЫ́ГИН** Аркадий Андреевич (1.5.1931, хәзерге Удмурт Респ-касының Кизнер а. — 27.4.2006, Казан), партия эшлеклесе. Әгерҗе тимер юл уч-щесен (1947), Красноярск тимер юл транспорты техникумын (1959), Бөтенсоюз тимер юл инженерлары читтән торып уку ин-тын (1965), КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясен (1970) тәмамлый. 1947 елдан Әгерҗе тимер юл станциясендә слесарь, бригадир, вагон депосы башлыгы урынбасары. 1962 дә КПССның Әгерҗе район ком-ты секретаре. 1962–67 дә КПССның Алабуга шәһәр ком-тында 2 нче, 1 нче секретарь. 1970–71 дә Алабуга пед. ин-ты проректоры. 1971–76 да КамАЗда партия ком-ты секретаре. 1976–86 да КПССның Татарстан өлкә ком-тында оборона сәнәгате, икътисад, партия эшен оештыру бүлекләре мөдире. 1986–90 да Татарстан өлкә ком-тында 2 нче секретарь. 1990–99 да Казан исәпләү системалары фәнни-тикшеренү ин-ты директоры урынбасары. 1999–2006 да «В.И.Шимко исем. «Радиоэлектроника» федераль фәнни-җитештерү үзәге» ДУП ген. директорының 1 нче урынбасары, киңәшчесе (бүленеп: 2004 тә «Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Казан радиоэлектроника фәнни-тикшеренү ин-ты» ДУП директоры). 1980–90 да ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

**РОЖДЕ́СТВЕНКА** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 30 *км* көнбатыштарак, Кичү елгасы буенда. 2010 елда 6 кеше (руслар) яши. 1782 гә кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Староверовка исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тәгәрмәч ясау б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, 2 иске дин тарафдарлары гыйбадәтханәсе, су тегермәне, 1905 тә чиркәү-приход мәктәбе, икмәк саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 493,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Акташ волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1782 дә — 14 ир-ат; 1795 тә — 44, 1841 дә — 85, 1859 да — 105, 1870 тә — 141, 1884 тә — 152, 1905 тә — 238, 1912 дә — 237, 1920 дә — 233, 1926 да — 226, 1938 дә — 230, 1949 да — 132, 1958 дә — 128, 1970 тә — 44, 1979 да — 24, 1989 да — 8, 2002 дә — 6 кеше.

**РОЖДЕ́СТВЕНО** (Би авылы) авылы, Лаеш р-нында. Казан тимер юл станциясеннән 41 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 229 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, кошчылык, яшелчәчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Троица чиркәве чаң каланчасы — 19 йөз уртасы архит-ра истәлеге. 1617 дән мәгълүм; рев-циягә кадәрге чыганакларда Укречь исеме б-н дә билгеле. Халкы — сарай, 1797 дән удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, сарык тиресе эшкәртү һәм йон тетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Троица чиркәве (1830–52 дә төзелә), земство мәктәбе (1868 дә төзелә), Халыкта аек яшәү рәвеше тәрбияләүче попечительлек өяз ком-ты уку өе, су һәм җил тегермәне, тимерче остаханәсе, 2 ярма яргыч, йон-тукыма ману йорты, 2 сырахәнә, 1 казна шәраб һәм 5 вак-төяклəр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1400,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Әстерхан волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 177, 1859 да — 379 ир-ат; 1897 дә — 1102, 1908 дә — 1220, 1920 дә — 1317, 1926 да — 1360, 1938 дә — 1876, 1949 да — 1021, 1958 дә — 560, 1970 тә — 517, 1979 да — 480, 1989 да — 330, 2002 дә — 279 кеше. Р. янында *Рождествено комплексы* урнашкан.

**РОЖДЕ́СТВЕНО КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Лаеш р-ның Рождествено авылы янында урнашкан. Р.к. истәлекләре 1948, 1951–52 елларда — Н.Ф.Калинин, 1956–58 дә —



Лаеш районы Рождествено авылы янындагы Имәнкискә культурасы каберлекләреннән табылган әйберләр.

В.Ф.Генинг, 1970–82 дә П.Н.Старостин һ.б. тарафыннан тикшерелә. Бронза гасыр, Казан яны, Азелино, Имәнкискә, Болгар һ.б. археол. культураларның торулыкларын һәм каберлекләрен үз эченә ала. Р.к. терр-ясендәге казулар барышында Мишә култыгының төньяк яры буенда В.Ф.Генинг җитәкчелегендәге археологлар төркеме тарафыннан соңгы бронза гасыр каберлекләре, торак калдыклары б-н Имәнкискә культурасы торулыгы, тулы киемнәрдә яндырып күмү йоласы сакланган каберлек (каберләрдә янган пыяла һәм таш муенсалар, эрегән бронза пычаклар, кием бизәмәләре һәм өлешләре: асылмалар, тагылмалар һ.б.), ш.у. эчендә органик калдыклар (фаразланганча, боткалы) булган балчык савытлар табыла. Мишә елгасының уң ярында землянкалар б-н болгар торулыкларының калдыклары өйрәнелә. Культура катламының әйберләр комплексында көнкүреш предметлары, монголларга кадәрге чор болгар культурасы керамикасы билгеләнә. V Рождествено каберлегендә (1970 тә ачыла) 273 кабер ачыла, аларның 1 се — соңгы бронза гасырга, 101 е — Азелино археол. культурасына, 171 е болгар (мөселман) культурасына карый. Азелино культурасына нисбәтле ир-ат каберләрендә (якынча, 3–5 йөзләр) — ат сөякләре, сугыш кораллары (кылычлар, сөңге очлыклары, тимер көбәләр, шишәкләр һ.б.), хатын-кыз каберләрендә (аларда да ат калдыклары табыла) бизәнү әйберләре һәм кием детальләре булуы ачыклана. Кайбер мөселман каберләрендә 14–15 йөзләргә нисбәтле аерым әйберләр (асма бизәкләр) табыла. 21 йөз башына Р.к.ның күпчелек истәлекләре, Куйбышев сусаклагычы сулары б-н юылып, тәмам югалуга дучар ителә.

*Әд.:* Ш п и л е в с к и й С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; Археологические памятники у села Рождествено. К., 1962.

*П.Н.Старостин.*

**РОЖДЕ́СТВЕНСКИЙ** посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 47 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тимерлек елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 1 кеше яши. 1910 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Казан губернасының Чистай өязе Иске Әлмәт волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1920 дә — 161, 1926 да — 157, 1949 да — 99, 1958 дә — 97, 1970 тә — 61, 1979 да — 34, 1989 да — 5, 2002 дә — 2 кеше.

**РОЖКО́В** Пётр Кузьмич (7.7.1920, Казан — 30.4.1999, шунда ук), слесарь-механик, Соц. Хезмәт Герое (1980). Казан ун-тында (1936 дан), Казан авиация ин-тында (1946 дан), Казан радиоэлектроника фәнни-тикшеренү ин-тында (1951–99) эшли. Герой исеме бердәм гомумгаскәри радиолокацион тану системасын булдыруда катнашканы өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**РО́ЗА**, г ө л җ и м е ш (Roza), роза чәчәклеләр семьялыгыннан яфрагын коючан куаклар ыругы. 400 гә якын төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача һәм субтропик поясларында таралганнар. Татарстан терр-ясендә кыргый үсүче 5 төре бар. Эт борыны (әрсез гөлҗимеш) (R. canina) һәм май Р.сы (R. majalis) барлык районнарда да очрый; энәле Р. (R. aciculfris), яланъяфраклы Р. (R. glabrifolia) һәм вак гөлҗимеш (R. rugosa) — сирәк төрләр. Далаланган ерымнарда, куаклыкта, сулык ярларында үсәләр. Сабагы туры, 50–200 *см* биеклектә, һәрвакыт диярлек энәле. Яфраклары чиратлашкан, парсыз-каурыйсыман, төпчек яфраклы. Чәчәкләре ике җенесле, берле яки чатыр-себеркәч чәчәк төркемендә, җиңелчә генә хуш исле, бөҗәкләр б-н серкәләнә. Җимеше — бер орлыклы чикләвекчек. Июнь–июльдә чәчәк аталар. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан, тамыр үрентеләреннән үрчиләр. Күп кенә кыргый төрләре суыкка, корылыкка чыдам, туфракка талымсыз. Кисүне яхшы кичерә. Җимешләреннән ясалган төнәтмә, сироп, чәй ялкынсынуга каршы, бәвел һәм үт кудыру өчен кулланыла. Р.ның 25 меңгә якын сорты һәм формасы исәпләнә. Культуралы һәм кыргый төрләре декоратив бакчачылыкта файдаланыла. Җимешләре б-н кошлар һәм вак имезүчеләр туклана.




Вак гөлҗимеш.

**РО́ЗА ЧӘЧӘКЛЕЛӘ́Р**, р о з а ч а л а р, ике өлешле үсемлекләр. Бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр, куаклар һәм агачлар. 100 дән артык ыруг һәм якынча 3 мең төре билгеле; бөтен Җир шарында диярлек, башлыча Төньяк ярымшарның уртача һәм субтропик зоналарында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 21 ыругы һәм 91 төре бар. Яфраклары чиратлашкан яки каршыдаш, гади яки катлаулы, төпчек яфраклы. Чәчәкләре ак, алсу, ачык кызыл төстә, берле яки чук, калкан, себеркәч чәчәк төркемендә, 5 өлешле чәчәк тирәлекле. Җимешләре — күптабакча, тартмачык, каты төшле алма. Р.ч. арасында — төшле, каты төшле һәм җиләкле җимеш культуралары (*алмагач, груша, чия, кура җиләге*, каен җиләге һ.б.), декоратив (*тубылгы куагы, роза, миләш*), дарулы (*тәпичә*, кура җиләге, *кызылбаш, дуләнә*), витаминлы (*гөлҗимеш*, миләш), баллы (*кара бөрлегән*, кызылбаш, *бишьяфрак*, алмагач һ.б.) үсемлекләр күп. Тәбәнәк *бадәм*, ак тәпичә, төз тәпичә, сары мәтрүшкә яфраклы тубылгы куагы ТРның Кызыл китабына кертелгән.



П.К.Рожков.



О.Ф.Розен.

**РО́ЗАНОВА** Галина Ивановна (31.12.1913, Тверь губ. Красный Холм ш. — 1.3.1987, Кама Тамагы р-ны Тәмте а.), агроном — җиләк-җимеш үстерүче, селекция белгече, ТАССР, РСФСРның атказ. агрономы (1968, 1982). Җиләк-җимеш-яшелчәчелек ин-тын тәмамлый (Тамбов өлкәсенең Мичурин ш., 1936). 1936–69 елларда Татарстан җиләк-җимеш тәҗрибә станциясендә. 1969–79 да Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында. 11 алма сорты авторы, шуларның 4 се Татарстанда районлаштырылган: «*Ренет Татарский*», «*Волжская красавица*», «*Ренет Поволжья*», «Теньковская». Грушаның 8 элита формасын чыгара. «Минзәлә» чия сорты автордашы. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Яблоневый сад. К., 1943 (автордаш).

*Әд.:* Юбилей селекционера // Садоводство. 1973. № 12; Садоводы — учёные России: Краткий биогр. справ. Орёл, 1997.

**РО́ЗЕН** (фон Розен) Отто-Стефан-Иоганн (Отто Фёдорович) (22.6.1778, Ревель губ., Ервен өязе Кикель утары — 12.4.1828, Казан), дәүләт эшлеклесе, барон, статский советник (1826). 1794 елдан хәрби хезмәттә. 1812 елгы Ватан сугышында һәм 1813–15 еллардагы чит илләргә яуларда катнаша. 1809–12 дә, 1816–18 дә, 1824–26 да Эстляндия губернасының полиция һәм мәхкәмә органнарында. 1818–24 тә Эстляндия губернасы дворяннары башлыгы. 1826 дан Казан гражданнар губернаторы. Казан губернасында раскольникларны эзәрлекли, кораб төзелеше урманнары Низовой округы түрәләренең лашманнарга карата законсыз гамәлләре б-н көрәшә. Казан, Зөя һәм Болгарда борынгы һәйкәлләрне барлап тасвирларга ярдәм итә (1827–28). Казан уку-укыту округының элекке попечителе М.Л.Магницкийны Казаннан Ревель шәһәренә җибәрергә булышлык итә (1826). Р. вакытында губерна шәһәре урамнарына таш түшәлә башлый, Казан ун-ты клиникалары өчен бина салына (1828).

*Әд.:* Д о л г о р у к о в П.В. Российская родословная книга. СПб., 1855. Ч. 2; Р о з е н А.Е. Очерк фамильной истории баронов фон-Розен. СПб., 1876.

*Е.Б.Долгов.*

**РО́ЗЕН** Фридрих Фридрихович (2.5.1834, С.-Петербург — 15.3.1902, Казан), геолог-минералог, минерал. һәм геогнозия д-ры (1867), проф. (1868). Дерпт ун-тын тәмамлый (1863), Казан ун-тында эшли (1896 елга кадәр), ми-

нерал. каф. мөдире (1865 тән), берничә тапкыр физика-матем. ф-ты деканы; бер үк вакытта (1868–81) Вет. ин-ты директоры вазифаларын башкаручы. Хезмәтләре Идел буе төбәгенең геологиясе һәм минералогиясенә карый. Р. Казан губернасы терр-ясендәге неоген-дүртенчел чор утырмалары төзелешен җентекләп тасвирлый. Казан ун-тының Минерал. музеен үзгәртеп оештыра. Казан табигыятьчеләр җәмгыятен оештыручыларның берсе. 1881 елда ун-тның студентлар сходкасын яклап чыккан бердәнбер профессор.

Х е з м.: Предварительный отчёт о геологических исследованиях в Казани и её окрестностях // Протоколы заседаний Об-ва естествоиспытателей при Имп. Казан. ун-те за 1869–70. 1870. Ч. 1; О послетретичных образованиях по Волге и Каме в Казанской губернии // Тр. 4 съезда Рус. естествоиспытателей в Казани. К., 1879.

**РОЗЕНГА́РТЕН** Михаил Юрьевич (13.2.1924, Харьков ш. — 4.1.2002, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1972), ТАССРның атказ. табибе (1979). Томск мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1944), Бөек Ватан сугышы фронтларында хирург буларак катнаша. 1945 елдан Томск өлкәсе һәм Томск шәһәрендәге мед. оешмаларында эшли. 1958 дән Казандагы сугыш инвалидлары госпиталендә дәвалау бүлеге мөдире. 1959 дан ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгы баш хирургы. 1991 дән «Татарстан иминият медицинасы» компаниясе баш эксперты, баш хирургы. Хезмәтләре кискен эчәк авыруларына диагноз кую һәм аларны хирургик дәвалауга карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Случай остановки сердца во время операции с последующей резекцией лёгкого // Казан. мед. журн. 1961. № 3; О патогенезе и профилактике вторичных кровотечений при экстраплевральном пневмолизе // Казан. мед. журн. 1964. № 1 (автордаш); Об определении состояния внутристеночного кровотока кишки при лапаротомии // Тр. Казан. ГИДУВа. 1969. Т. 26; Определение жизнеспособности кишечных петель при лапаротомии // Казан. мед. журн. 1970. № 4.

**РОЗЕНЦВА́ЙГ** Александр Куртович (4.12.1947, Юдино р-ны Олы Ключи а.), механика өлкәсе белгече, техник фән. д-ры (2005). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1970–81 елларда Татарстан нефть фәнни-тикшеренү һәм проект ин-тында эшли (Бөгелмә ш.), нефть, газ һәм суны җыю, транспортлау һәм әзерләү бүлегендә сектор мөдире. 1981 дән Кама инженерлык-икътисад академиясендә (хәзер Казан ун-тының Чаллы ин-ты, Чаллы ш.), икътисадта матем. модельләштерү һәм мәгълүмат технологияләре каф. профессоры. Хезмәтләре механика өлкәсенә, үзара катнашмаучан сыеклыкларның катлаулы дисперс системаларында күчерү процессларын матем. модельләштерүгә карый. Р. торба үткәргечләрдә һәм технологик аппаратларда су-нефть эмульсияләренең дисперс фазасын эреләндерү һәм аеруның рациональ гидродинамик параметрларын исәпләү методикасын эшли. Үзара катнашмаучан сыеклыкларның гетероген системаларында җылылык һәм масса күчерү кебек катлаулы физик-химик процессларны анализлауга яңача якын килә. Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Дробление капель в турбулентном сдвиговом потоке разбавленных жидкостных эмульсий // Прикладная механика и техн. физика. 1981. № 6; Коалесценция дисперсной фазы жидкостных эмульсий // Журн. прикладной химии. 1986. № 10; Структурный анализ механизмов взвешивания частиц в турбулентном потоке жидкостных дисперсных систем // Изв. вузов. Проблемы энергетики. 2003. № 9–10; Сопряжённое моделирование и конструирование пульсационных аппаратов. К., 2005 (автордаш).

**РОЗО́ВСКАЯ** Тамара Петровна (8.10.1930, Мәскәү), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1977). Мәскәүнең 2 нче мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), Мәскәү өлкәсе Лотошкино посёлогы хастаханәсендә табиб-хирург, 1961 елдан — хирургия бүлеге мөдире. 1963 тән Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында, 1978–91 дә кул чугы зәгыйфьлеге һәм авырулары бүлеге мөдире. Хезмәтләре кул чугы хирургиясенә карый. Уйлап табуга 4 патенты бар. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Отдалённые результаты лечения больных с контрактурой Дюпюитрена // Казан. мед. журн. 1981. № 6 (автордаш); Исходы лечения открытых повреждений кисти и пальцев // Советская медицина. 1984. № 12 (автордаш); Инвалидность при сочетанной травме кисти // Советская медицина. 1987. № 1 (автордаш).

**РОЙТФА́РБ** Григорий Зельманович (7.11.1937, Украина ССРның Житомир ш.), тромбончы, педагог, ТАССРның халык артисты (1987). 1966 елда Казан консерваториясенең оркестр ф-тын (Ш.Низаметдинов классы) тәмамлый. 1963 тән Татар опера һәм балет театры оркестры артисты, 1970–94 тә ТРның Дәүләт симф. оркестрында. Бер үк вакытта, 1966–2000 дә, Казан консерваториясендә укыта (1993–96 да тынлы җиз музыка уен кораллары каф. мөдире). Концерт эшчәнлеге алып бара. Идел буе композиторларының тромбон өчен язылган әсәрләрен беренче башкаручы. Тромбонда уйнау өчен эшкәртмәләр (ш.и. Р.Яхин әсәрләрен) авторы. Р.ның башкаруын югары проф. осталык, сирәк очрый торган матур аһәң, чиста интонация аерып тора. 2001 дән Израильдә яши.

**РОКА́ШЕВО** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 70 *км* төньяк-көнбатыштарак, Казан — Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 34 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Романовка исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу, арба, чана, тәгәрмәч һәм тугым ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Покров чиркәве (1881 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1880 нән эшләүче чиркәү-приход мәктәбе урынында 1882 дә ачыла), 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1168 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Зирекле волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1782 дә — 34 ир-ат; 1859 да — 261, 1870 тә — 308, 1897 дә — 487, 1908 дә — 499, 1920 дә — 554, 1926 да — 528, 1938 дә — 385, 1949 да — 316, 1958 дә — 306, 1970 тә — 197, 1979 да — 60, 1989 да — 25, 2002 дә — 46 кеше.

**РОКИТЯ́НСКИЙ** Вадим Иванович (18.8.1910, Харьков губ. Сениченко хуторы — 25.9.1972, Казан), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1966), проф. (1970). Мәскәүнең 2 нче мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1938), Мәскәү физик культура фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1941 елдан хәрби-мед. хезмәттә, 1953 тән Үзәк табибләр белемен күтәрү ин-тының (Мәскәү) травматология һәм ортопедия кафедрасында, 1956 дан Ортопедия һәм травматология фәнни-тикшеренү ин-тында (Свердловск ш.), 1962 дән Новокузнецк ГИДУВында, 1964 тән Курортлар һәм физиотерапия фәнни-тикшеренү ин-тының (Сочи ш.) физик дәвалау ысуллары бүлеге башлыгы. 1969 дан Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында. Хезмәтләре тез буыннары эшчәнлеген торгызуга, имгәнүләрне комплекслы дәвалаганда индуктотермия һәм ультратавыш куллануга карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Физические методы лечения повреждений у физкультурников и спортсменов. М., 1956; Ультразвук и его лечебное применение. М., 1970 (автордаш); Физические методы лечения в травматологии и ортопедии. Киев, 1970.

**РОКИ́ЦКИЙ** Михаил Рафаилович (28.9.1931, Ленинград), балалар хирургы, мед. фән. д-ры (1969), проф. (1970), ТР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1991, 1997). Куйбышев мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1955), «Первомайбурнефть» идарәсе мед.-сан. частенда хирургия бүлеге мөдире. 1958 елдан Куйбышев мед. ин-тының хирургия кафедрасында. 1960–67 дә Белоруссия ГИДУВының күкрәк балалары һәм балалар хирургиясе кафедрасында, 1961 дән ясалма кан әйләнеше лаб-ясе башлыгы. 1967–99 да Казан мед. ун-тының балалар хирургиясе каф. мөдире. Хезмәтләре балаларда үпкә авыруларын хирургик дәвалауга карый. Россия балалар хирурглары ассоциациясенең шәрәфле әгъзасы (1996). ТР Дәүләт бүләге балалар хирургиясендә яңа технологияләр эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә (1997). 1990–93 тә — РФ халык депутаты, 1999–2007 дә РФ Дәүләт Думасы депутаты. Медальләр, ш.и. 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале; ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Неотложная пульмонология детского возраста. Л., 1978; Ошибки и опасности в хирургии детского возраста. Л., 1979; Лёгочные кровотечения у детей. Л., 1983; Хирургические заболевания лёгких у детей. Л., 1988; Этика и деонтология в хирургии. М., 1988.

*Әд.:* Профессор Михаил Рафаилович Рокицкий // Казан. мед. журн. 2001. № 6.

*В.Ф.Богоявленский.*

**РОМАДА́НОВСКИЙ** Сергей Михайлович (16.9.1949, Югары Ослан р-ны Юмат а.), спортчы, тренер (бокс), РСФСРның атказ. тренеры (1991). Казан авиация техникумын (1968), Волгоград физкультура ин-тының Чаллы ф-лын (1991) тәмамлый. Техникумда укыганда бокс б-н шөгыльләнә (тренеры — Г.Штейнгарт). 1968–70 елларда Совет Армиясе сафларында чагында шөгылен дәвам итә. 117 бокс сугышында катнаша, шуларның 99 ында җиңүче була. 1971 дән «Зенит» ирекле спорт җәмгыятендә тренер (Казан). Шәкертләре арасында — Ф.Ә.*Гатин*, бөтенсоюз һәм бөтенроссия ярышларында беренчә тапкыр җиңүче һәм медаль алучы В.Балашов, А.Зәйнетдинов.

**РОМА́Н** (франц. roman), аерым кешенең язмышын, аның тирәлек б-н каршылыкларын, шул вакыттагы эчке кичерешләрен, характеры һәм үзаңы үсүен, шәхси тормышының иҗтимагый мәгънәсен күрсәтеп хикәяләү, әдәби жанр, зур күләмле эпик әсәр. Жанр авторга геройларның рухи дөньясындагы үсеш-үзгәрешләрне күзәтергә, аларның характерлары формалашу һәм үсү шартларын анализларга мөмкинлек бирә. Мөстәкыйль хикәяләү жанры буларак Р. татар әдәбиятында 19 йөзнең 2 нче яртысында барлыкка килә. Башта мәгърифәтчелек әдәбиятына хас, үгет-нәсихәт бирүгә, сюжет төзелешен билгеле бер тезисны раслау яки кире кагуга, персонажлар системасына автор идеяләрен йөрткән геройларны кертүгә корылган Р.нар языла (М.Акъегетнең «Хисаметдин менла», З.Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә», «Гөнаһе кәбаир» кебек әсәрләре — беренче Р. үрнәкләре). Р.ның жанр буларак барлыкка килүе татар әдәбиятының Көнбатышка йөз тотуына гына түгел, ә авторларның уку-укыту системасын яңартырга һәм камилләштерергә омтылуына да бәйле. Жанр төрләре татар җәмгыяте тормышын сәнгати яктан тулаем күрсәтергә мөмкинлек бирә. Әйтик, Г.Исхакый иҗтимагый-психол. «Теләнче кызы» Р.ында татар хатын-кызының милләт киләчәге өчен көрәш юлына басуын күрсәтә, социаль тигезлек мәсьәләсен күтәрә; «Тормышмы бу?» психол. Р.ында яшь буынны тәрбияләү һәм укытуда искергән дини канунар һәм ышануларга сукырларча иярүнең фаҗигасен ача; иҗтимагый-тарихи «Мулла бабай» Р.ында татар җәмгыятендәге ислам традицияләренең ролен күрсәтә. Г.Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» Р.ны б-н бергә татар әдәбиятында мөстәкыйль сәнгати юнәлеш булып романтизм формалаша. Ф.Әмирханның «Урталыкта» Р.ны 20 йөз башы татар зыялыларының рухи эзләнүләрен бәяләве ягыннан үзенчәлекле.

1920 еллар уртасыннан Р. жанры үсеп китә. Авторлар иске тормыш тәртипләренең җимерелүен, яңалары туууын, аларның кеше аңына һәм язмышына фаҗигале тәэсирен эстетик яктан аңлатырга тырышалар. Бу чорның иң танылган әсәре Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар» Р.ны (эчтәлеге — иҗтимагый-революцион, формасы — детектив) була. Бу тенденция Ш.Камалның «Таң атканда» һәм «Матур туганда» героик-революцион, М.Галәүнең «Кабулсай» Р.нарында дәвам итә. Милли традицияләрне гәүдәләндерү һәм саклап калуга омтылу М.Галәүнең «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр», Г.Ибраһимовның «Казакъ кызы» Р.нары язылуга китерә. Берникадәр тукталып торганнан соң, 1950 елларда Р. яңарыш чорын кичерә һәм әдәбиятны яңа типтагы әсәрләр б-н баета: Г.Әпсәләмовның героик-романтик «Алтын йолдыз», К.Нәҗминең героик-революцион «Язгы җилләр», Ф.Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы», Г.Әпсәләмовның биографик «Газинур», И.Газиның «Онытылмас еллар», Ә.Фәйзинең «Тукай», Г.Бәшировның иҗтимагый-психол. «Намус», М.Әмирнең «Саф күңел» Р.нары шундыйлардан. Р. жанры, дәрәҗәләр хилафлык китермичә, тарихи үзгәрешләр чоры вакыйгаларын бөтен нечкәлекләре б-н кабатлап тасвирларга, кешенең эчке дөньясындагы тирбәлешләрне күзәтергә мөмкинлек бирә. Бөек Ватан сугышы темасы Г.Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше», Ш.Маннурның «Муса» документаль Р.нарында дәвам итә. Аларда сугыш кансыз күренешләр һәм совет идеологиясе патетикасы бердәмлегендә тасвирлана. Авторлар авыр сугыш һәм әсирлек шартларында кеше психологиясен сурәтләүгә күбрәк игътибар бирә башлыйлар: Ш.Рәкыйповның «Йолдызлы төннәр», Х.Камаловның «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр» Р.нары шундыйлардан.

Г.Ахуновның «Хәзинә», Г.Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар», И.Газинең «Гади кешеләр» һ.б. производство романнарында төп герой бәхетен хезмәттә таба, хезмәт шәхесне, аның аңын, фикерен, карашларын камилләштерү чарасы буларак бәяләнә. 1960–70 елларда тарихи һәм иҗтимагый-психол. яссылыкларны берләштергән романнар языла. Тарихи җирлек Гражданнар сугышы елларында татар җәмгыятендә барган үзгәрешләрне (С.Батталның «Чирмешән ярларында» шигъри Р.ы), В.И.Ленинның революцион эшчәнлеген (Г.Әпсәләмовның «Күк күкрәр» Р.ы) колачлый, иҗтимагый-психол. планда шәхескә караш совет идеологиясе күзлегеннән сурәтләнә. Ләкин 1960 елларның 2 нче яртысыннан башлап татар әдәбиятында героик тенденциягә тискәре мөнәсәбәт урнаша һәм беренче планга әхлакый бурыч, сайлау мәсьәләсе килеп баса. Җәмгыятьтәге әхлакый тупаслану, акрынлап милли тамырларны югалта бару язучыларны бу күренешләрнең сәбәпләре турында уйланырга, аларны «эчтән», кеше психологиясеннән эзләргә этәрә. Тәүбә прозасы, беренче чиратта Р. материалында, рухи торгынлыктан чыгу юлларын барлый, бер үк вакытта совет җәмгыяте нигезләрен һәм кеше әхлагының түбәнәюен тәнкыйди бәяләү башлана (Г.Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр», А.Гыйләҗевнең «Урамнар артында яшел болын», А.Расихның «Ике буйдак», «Сынау» Р.нары). Авторлар көнкүрештәге кимчелекләрне бөтен нечкәлекләре б-н, «эчтән», бюрократик каршылыкларга, яхшылык һәм хакыйкать төшенчәләренең бозып аңлатылуына, әхлакый нигезләрнең җимерелүенә тап булган кешеләр күзлегеннән тасвирлыйлар.

Хакыйкать эзләп, язучылар халыкның үткәненә мөрәҗәгать итәләр. Нәкъ менә тарихи Р.нарда татар әдәбиятының идея-эстетик юнәлеше алмашына (Н.Фәттахның «Итил су ака торур», «Сызгыра торган уклар», М.Хәбибуллинның «Илчегә үлем юк», «Шайтан каласы», «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный», Р.Батулланың «Сөембикә», Ф.Латыйфинең «Хыянәт» Р.нары).

1920–30, 1930–50 еллар вакыйгаларының асылын аңларга омтылып, язучылар аерым бер кеше язмышына карата рәхимсез чорны каршылыклы вакыт буларак тергезәләр. Г.Ахуновның «Идел кызы», Г.Бәшировның «Гыйбрәт» Р.нарында әдипләр үзләре шаһит булган фаҗигале вакыйгалар бәян ителә, әхлакый кыйммәтләрнең буталуы, рухи югалтулар тарихы сурәтләнә. Кырыс иҗтимагый сынауларга каршы торырлык бердәнбер көч итеп кешеләр арасындагы җылы мөнәсәбәтләр күрсәтелә, туганлык, берләшү, туган илгә мәхәббәт иң мөһим кыйммәтләрдән санала. Кайбер Р.нарда кешедәге рухи ярлылыкка табигать каршы куела, әхлакый тамырларга кире кайтырга өндәү яңгырый (Г.Бәширов. «Җидегән чишмә»). Шигъри Р.нарның яңадан кайтуы традицияләрне яңарту кебек кабул ителә (Ә.Давыдов. «Йокысыз төннән соң», Р.Харис. «Исемсезләр»).

1980–90 еллар Р.нарында фәлсәфи яктан чишелеш тапкан төп темаларның берсе тоталитар шартларда зыялыларның фаҗигасе, шуннан килеп чыккан коточкыч әхлакый нәтиҗәләр була (А.Гыйләҗев. «Балта кем кулында?», М.Хәсәнов «Язгы аҗаган», Ф.Сафин. «Саташып аткан таң», В.Имамов. «Тозлы яра»). Бу әсәрләрдә заман төгәл-тарихи (совет идеологиясе) һәм символик (шәхеснең тапталуы) яктан чагылдырыла. «Лагерь прозасы»нда (Г.Тавлинның «Афәт», Р.Мөхәммәдиевнең «Сират күпере», А.Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога!») авторлар геройларның әхлакый йөзен яшәү б-н үлемгә мөнәсәбәтеннән чыгып билгели. Шәхес культы чоры — газаплар юлы, тормыш хакыйкатенә төшенү, революция елларында туган өметләрнең чәлпәрәмә килүе буларак тасвирлана.

20–21 йөзләр чиге атмосферасы Р. жанрының юнәлешен кабат алмаштыра: ул социаль гаделсезлеккә каршы тору формасына әйләнә, тормышка фәлсәфи һәм әхлакый карашны тамырдан үзгәртергә мәҗбүр итә. Ф.Садриевның «Таң җиле», Ф.Латыйфинең «Ишелеп төшкән бәхет» Р.нарында ялганга нигезләнгән совет чынбарлыгының ирекне бууы тасвирлана, әхлакый традицияләрне, милли үзенчәлекне югалту, милли үзбилгеләнү зарурлыгы ачыклана. Язучы җәмгыятьнең генә түгел, яшәеш кануннарының да камил булмавына борчыла. Ф.Садриевның «Бәхетсезләр бәхете» Р.-трилогиясендә совет идеология системасы шәхесне массага әйләндерүче «җимергеч машина» итеп карала, автор үзгәртеп кору чорын элекке режимның дәвамы итеп күзаллый. Т.Галиуллинның «Сәет Сакманов» Р.-трилогиясендә үзгәртеп кору чоры кансызлык дәвере, җинаятьчеләр һәм җинаятьләр дәвере буларак тасвирлана. Уңай геройларның булмавы рухи

торгынлык чорында гомумкешелек кыйммәтләренең югала баруын күрсәтә. Ф.Бәйрәмованың тоталитар режим шартларында татар милләте язмышы темасын дәвам иткән «Караболак» Р.ында (Чиләбе өлкәсендәге шул исемдәге татар авылының радиацион катастрофа кичерү вакыйгалары сурәтләнә) үз халкыңа каршы юнәлтелгән идеологияне явызлык дип бәяләүче тәнкыйди башлангыч б-н документаль башлангыч берләштерелә. З.Хәкимнең «Гөнаһ» Р.ында «гөнаһ» — «җәза» — «чистарыну» төшенчәләренең үзара бәйләнеше ачыклана. Әсәрнең идеясен җәмгыять, аерым кеше кебек, тәүбәгә килергә тиеш дигән фикер тәшкил итә. Ф.Бәйрәмованың «Агымсуда ни булмас» социаль антиутопиясендә сатирик төстә хәзерге авыл, анда яшәүчеләрнең көнкүреше тасвирлана. Әсәрләрдә совет чорын һәм үзгәртеп корулар чорын сатирик бәяләү алга чыга. Т.Миңнуллинның маҗаралы әсәр итеп уйланылган «Минһаҗ маҗаралары» Р.ы 19 йөз ахырыннан башлап Николай II хакимлек иткән чорга кадәр милли тарихны киң масштаблы пародия рәвешендә күрсәтә. 20 йөзнең танылган сәясәтчеләре б-н төп геройның егерме бер тапкыр очрашуы — авторның ил тарихын идеологик мифлардан арындыру омтылышы.

Татар әдәбиятында Р.ны сюжет моделе, дискуссияләрнең, төрле дәверләрдәге идеологияләр үрелеше, кеше аңына һәм күзаллауларына мөрәҗәгать итү буларак файдалану бу жанрда интеллектуаль башлангычның көчәюенә китерә. Разил Вәлиевнең «Мирас» Р.ында 20 йөзнең төрле чорларына хас көнкүреш һәм сәяси билгеләрнең бер текст эчендә очрашуы аша күпкатламлы шәрехләүгә ирешелә. Г.Гыйльмановның «Албастылар» Р.ында мифка йөз тоту кешене яшәү мәгънәсен эзләүче зат буларак карарга мөмкинлек бирә. Автор күптөрле параллель дөньяларны тасвирлый, һәм бу фонда яшәү мәгънәсе үз «мин»ен, асылын табып белү аша раслана. Р.Сибатның «Ялгызак» Р.ында әхлак мәсьәләләре хакыйкатьне фәлсәфи эзләү б-н үрелгән; кеше концепциясе «йомык» дөнья кебек күзаллана. Милли характер мәсьәләсен хәл итүне ул индивидуальлекне раслауда күрә.

20–21 йөзләр чигендә, яңа иҗтимагый-идеологик шартларда, татар әдәбиятында ислам кануннары һәм гореф-гадәтләре б-н таныштыручы, диннең мөһимлеген исбатлаучы, әчтәлеге б-н дидактик-мәгърифәтчел, шулай ук иҗтимагый фикернең әхлакый-фәлсәфи эзләнүләрен бер төенгә тоташтырган Р.нар языла.

*Әд.:* Хатипов Ф.М. Эпик жанрлар. К., 1973; Бәширов Ф.К. XX йөз башы татар прозасы. К., 2002; Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында. К., 2006; Рымарь Н.Т. Поэтика романа. Куйбышев, 1990; Эсалнек А.Я. Типология романа (Теоретические и историко-литературные аспекты). М., 1991; Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и Восточная классика. К., 1993.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**РОМАНЕ́НКО** Леонид Георгиевич (19.10.1938, Петропавловск-Камчатский ш.), очкыч аппаратларның очышы б-н идарә итү системалары өлкәсе белгече, техник фән. д-ры (1998), проф. (2005). 1962 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, автоматика һәм идарә каф. профессоры (1998 дән), бер үк вакытта «Сокол» Тәҗрибә КБның баш белгече (1963–74 һәм 2002 дән). Хезмәтләре хәрәкәтләнүче объектлар б-н идарә итү системаларының алгоритм һәм структураларын төзүгә һәм автомат идарә системаларын синтезлау максатында оптималь полиномнар эшләүгә карый. Р. пилотаж-навигация комплекслары б-н идарә итү системаларының параметрларын исәпләү алымнарын, алгоритмнарын һәм структураларын тәкъдим итә. Аның тикшеренү нәтиҗәләре «Сокол» тәҗрибә КБның ерактан торып идарә ителә торган очкыч аппаратлар төзүгә караган эшләрендә куллану таба. Уйлап табуга 43 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР Космонавтика Федерациясенең акад. В.П.Макеев исем. медале б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре.

Хезм.: О поиске минимума интегральных квадратичных оценок // Изв. вузов. Авиац. техника. 1978. № 4; Оптимальные характеристические полиномы для колебательных переходных процессов // Изв. вузов. Авиац. техника. 1994. № 3; Проектирование систем управления полётом летательных аппаратов. К., 2004.

**РОМА́НОВ** Александр Осипович (15.2.1931, Мамадыш р-ны Албай а.), хакимият-хуҗалык, партия хезмәткәре, РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1991). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1970). Хезмәт эшчәнлеген 1949 елда Балык Бистәсе р-нының «Социализм» с-зы кырчылык бригадасында бригадир булып башлый. 1954–55 тә «Калининуголь» трестының (Донецк өлкәсе) Яңа Кондратьевка посёлогы шахтасында забойчы. 1956–67 дә «Бөрсет» җәнлек с-зында хисапчы, баш хисапчы урынбасары, Мамадыш р-ны халык контроле ком-ты рәисе (1967 дән), КПССның Питрәч район ком-ты секретаре (1972 дән), Татарстан «Зверопром» тресты директоры (1976 дан), «Татпушнина» АҖ ген. директоры (1988–96). «Почёт билгесе» ордены; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике алтын, бер көмеш, бер бронза медале; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**РОМА́НОВ** Андрей Анатольевич (11.7.1949, Казан), спортчы, тренер (ирекле көрәш), СССРның спорт остасы (1968), Россиянең атказ. тренеры (1995), халыкара категорияле судья (1988). Ленинград физкультура ин-тын тәмамлый (1977). Профсоюзларның «Буревестник» бөтенсоюз ирекле физкультура спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (тренеры — Ә.Ш.*Шәйхетдинов*). ТАССР беренчелекләрендә (1966–67, 1971–73), РСФСР зоналары беренчелекләрендә (1965) җиңүче, РСФСР чемпионатында көмеш медаль алучы (1965). 1970–87 елларда Тукай район советының «Урожай» ирекле спорт җәмгыятендә тренер, 1987 дән Балалар иҗаты үзәгендә өлкән тренер (Чаллы ш.). 1987–92 дә СССР, РСФСР җыелма командаларында тренерлык эшендә. 1990 нан Татарстан судьялар коллегиясе әгъзасы. Европа, дөнья чемпионатлары, дөнья кубогы, Игелекле уеннар, халыкара турнирларда һәм беренчелекләрдә судья буларак («Е» категорияле арбитр) катнаша. Халыкара һәвәскәр спорт көрәше федерациясенең мактау дипломнары б-н бүләкләнә (1997, 1998).

**РОМА́НОВ** Геннадий Васильевич (8.10.1946, Казан), химик, химия фән. д-ры (1986), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1995), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1968), шунда ук эшли. 1971 елдан РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, нефть химиясе һәм геохимиясе лаб-ясе мөдире (1981 дән), проф. (1992), бер үк вакытта Нефть чыгару химиясе фәнни-тикшеренү ин-тында ген. директор урынбасары (1998–2008). Хезмәтләре элементорганик кушылмаларга, нефть химиясенә, нефтьләр химиясе һәм геохимиясенә, табигый битумнарга карый. Р. Арбузов һәм Пудовик реакцияләренең электрохимик вариантларын эшләүдә катнаша. Ванадий, никель һәм аларның порфиринлы комплексларының нефть компонентлары буенча таралу закончалыкларын билгели һәм әлеге кушылмаларны аерып алуның яңа ысулларын тәкъдим итә. Калдык нефтьләр химиясен һәм геохимиясен тикшерә, бу өлкәдә яңа фәнни юнәлешкә нигез сала. Тикшеренү нәтиҗәләрен Р. төрле яшьтәге токымнарның калдык нефть запаслары формалашу механизмына йогынты ясаучы факторларны бәяләүдә; үтә үзле нефтьләр һәм табигый битумнарны ташуга һәм эшкәртүгә әзерләүнең яңа технологияләрен эшләүдә, алардан кыйммәтле кече тоннажлы химия продуктларын алуда; кайбер экологик мәсьәләләрне хәл итүдә куллана. Р. җитәкчелегендә нефть сәнәгатендә һәм мед. материаллары (кетгут) җитештерүдә файдалану өчен комплекслы тәэсир итүче реагентлар алына; скважиналар эшен файдалырак итү, катламның нефть бирүчәнлеген арттыру ысуллары эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 89 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997). Нефть химиясе мәсьәләләре буенча Казанда үткәрелүче респ-ка, бөтенроссия һәм халыкара форумнарны оештыручы һәм аларда актив катнашучы. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә (1997).

Хезм.: Органические гидрофосфины. М., 1985 (автордаш); Химия и геохимия пермских битумов Татарстана. М., 1999 (автордаш); Физико-химические проблемы повышения нефтеотдачи пластов // Рос. хим. журн. 1999. Т. 43, № 3/4 (автордаш).

*Әд.:* Поздравляем с золотым юбилеем // Науч. Татарстан. 1996. № 3; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**РОМА́НОВ** Григорий Григорьевич (23.9.1907, Казан губ., Чистай өязе Кәкрекүл а. — 28.6.1987, Алабуга ш.), Сов. Союзы Герое (21.2.1945), гв. капитаны. Татар коммунистик ун-тын (Казан, 1932), Хәрби сәяси курслар (1942) тәмамлый. Туган авылында уку йорты мөдире, авыл советы секретаре, рәисе булып эшли. 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 128 нче гв. укчы полкының тупчылар взводы командиры (65 нче армиянең 44 нче гв. укчы дивизиясе). 1 нче һәм 2 нче Белоруссия фронты гаскәр-

ләре составында Белоруссия (1944) һәм Млава-Эльба (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Сероцк шәһәреннән (Польша) төньяктарак Нарев елгасы янындагы плацдармны саклаганда батырлык күрсәтә: 1944 нең 5 октябрендә Р. командалыгындагы артиллеристлар Дзержинец авылы янында дошман контратакасын кире кайтарганда 5 танкны сафтан чыгаралар һәм зур төркем пехотасын юк итәләр; Р. яралана, ләкин сафта кала. Авыр яраланудан соң, 1945 тә, армиядән демобилизацияләнә. Туган авылында яши һәм эшли, аннары Алабуга шәһәренә күчә. 1946–54 тә СССР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә. Алабуга шәһәрендә Геройга бюст куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**РОМА́НОВ** Игорь Михайлович (12.8.1915, Казан — 19.10.1987, шунда ук), физик, физика-матем. д-ры (1974), проф. (1977), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1986). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1937), шунда ук эшли, электромагнитик тирбәнешләр лаб-ясе мөдире (1944–45), радиофизика каф. мөдире (1952–70), проф. (1975 тән). Хезмәтләре гомуми һәм оборона максатларында кулланыла торган радиоэлектрон системаларның үткәрү сәләтен бәяләү һәм күтәрү алымнарына; кыска дулкыннар өлкәсендә парамагнитик релаксациягә; ихтималый радиотелемеханик системалар теориясенә, кибернетик системалардагы элемтә каналларының үткәрү сәләтенә карый. «Гипотезалар анализаторлары һәм схоластик генераторлар» («Анализаторы гипотез и стохастические генераторы», 1968) җыентыгының фәнни мөхәррире. Татарстанда оештырылган 146 нчы укчы дивизиянең Калуга өлкәсендәге сугышчан эшләре буенча Казан ун-тының беренче «*Кар десанты*»*ның* (1969) фәнни җитәкчесе. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр; «СССРның мактаулы радисты» билгесе б-н бүләкләнә. Спас-Деменск шәһәренең (Калуга өлкәсе) мактаулы гражданы.

Х е з м.: Передающие линии и резонансные системы СВЧ. К., 1961; Асинхронные импульсные радиосистемы. К., 1967; Введение в теорию проектирования асинхронных импульсных радиосистем. М., 1971 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**РОМА́НОВ** Пётр Иванович (2.7.1835, Түбән Новгород ш. — 1889 дан соң), архитектор. Өяз уч-щесен тәмамлый, 1853–65 елларда Казан губернасының төзелеш һәм юл комиссиясендә сызымчы булып эшли, 1863 тә САндә читтән торып укыган архит-ра рәссамы дәрәҗәсенә имтиханнар тапшыра. 1865–74 тә Казан губерна идарәсенең төзелеш бүлеге архитекторы. Казанның Иске татар бистәсендә Р. проектлары буенча *Борнай мәчете* (1872), *Галиев мәчете* (1882), «*Касыймия*» мәдрәсә комплексы (1877–82), «*Мәрҗания*» мәдрәсәсенең (1880–81) төп бинасы һәм флигеле төзелә. Чистай өязенең Екатерининский бистәсендәге (1875), Лаеш өязенең Рус Сәрдәсе авылындагы (1879) чиркәүләрне, Казандагы иске дин тарафдарларының Спас-Преображение (1878) чиркәвен реконструкцияләү проектларын эшли. Күпчелеге Казанның татар бистәләрендә урнашкан байтак кына торак йортларны, аерым алганда И.И.Апаков йортын (1866, соңрак «*Болгар*» номерлары бинасы) проектлаштыра. Эклектика стиленең төрле юнәлешләрендә эшли.



П.И. Р о м а н о в. В.М.Яушев йорты (соңрак бертуган Кәримовларның Сәүдә йорты). 1883.

*Әд.:* О с т р о у м о в В.П. Казань. Очерки по истории города и его архитектуры. К., 1978; М у р т а з и н а Л.М. Архитекторы Казани XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999.

*Л.М.Мортазина.*

**РОМА́НОВА** Анна Ильинична (15.12.1973, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2003), проф. (2008). 1995 елда Казан төзүче инженерлар ин-тын (хәзер Казан архит-ра-төзелеш ун-ты) тәмамлаганнан соң шунда ук эшли: ассистент, өлкән укытучы, төзелеш икътисады һәм эшмәкәрлек каф. доценты, шәһәр хуҗалыгы икътисады һәм идарә итү каф. мөдире (2005 тән), Өстәмә белем бирү ин-ты директоры (2009 дан), бер үк вакытта, 1999–2000 елларда, Мәскәү икътисад, статистика һәм информатика ун-тының Казан ф-лында укыта. Төп хезмәтләре капиталь төзелешне үстерү стратегиясе, көндәшлеккә сәләтлелек, икътисади тотрыклылык һәм хәвефсезлек проблемаларына карый. «ТРда кластерлы яссылыкта 2020 һәм 2030 елларга кадәр җитештерү көчләренең үсеше һәм урнаштырылуы» программасын эшләүчеләрнең берсе.

Х е з м.: Вопросы планирования экономической устойчивости строительных предприятий. К., 2001; Конкурентоспособность строительных организаций: Теория и практика анализа. К., 2002 (автордаш); Долевое строительство: посоревнуемся? К., 2006 (автордаш); Перспективы развития инвестиционно-строительного комплекса Республики Татарстан. К., 2008.

**РОМА́НОВА** Ирина Петровна (24.7.1958, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (2008). 1979 елда Казан ун-тын тәмамлый. РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли (бүленеп: 1995–96 да В.И.Ленин исем. фәнни-җитештерү пр-тиесендә), гыйльми секретарь (2004 тән). Хезмәтләре фуллереннар химиясенә карый. Р. бор, азот, кислород һәм мышьяк катнашкан гетероциклларның фәзаи төзелешен бис(α-оксиалкил)фенилфосфиннар нигезендә синтезлый һәм тикшерә, табылган диоксафосфоринаннарның кайберләре фунгицид һәм бактерицид активлыкка ия икәнен күрсәтә. Электроннарны беренчел фуллерен $C_{60}$ тан җиңелрәк кабул итә торган циклорганофуллереннар табу максатында фуллеренның яңа моно- һәм бис-циклоаддуктларын (ш.и. фуллероимидазопиримидиннар һәм 5,6-ябык моноаддуктлар) синтезлый; аларның электрон куша алу сәләтен (ЭКС) бәяли. Фуллероазиридин һәм фуллероимидазопиримидин төзелешле моноаддуктларның ЭКС беренчел фуллерен ЭКСы б-н бер үлчәнешле яки аннан югарырак, ә циклоаддуктның азагомофуллерен төзелеше фуллерен сферасына гетероатомнар яки аларның алмашлары эффектын тапшыру өчен уңай икәнен билгели. Циклоаддуктларның ЭКСын көйләү һәм модификацияләнмәгән фуллеренныкына караганда югарырак ЭКС булган молекулалар тудыру мөмкинлеген күрсәтә (андый кушылмалар арзанлы кояш батареялары ясауда кулланыла).

Х е з м.: Взаимодействие гипофосфористой кислоты с бензальдегидом // Изв. АН СССР. Сер. хим. 1981. № 12 (автордаш); Органические акцепторы на основе производных [60]фуллерена // Вестн. Рос. фонда фундам. исследований. 2004. № 4 (автордаш); Synthesis and unusual electrochemical properties nitropyrimidine substituted diazadihomo ($C_{60}$-$I_h$)[6,6]fullerene // Mendeleev Commun. 2006. № 6 (автордаш).

**РОМА́НОВА** Нина Алексеевна (1.3.1926, Лаеш кантоны Балык Бистәсе а. — 11.9.2005, Казан), педиатр, мед. фән. д-ры (1976), проф. (1979). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1948), Чита өлкә балалар йогышлы авырулары хастаханәсендә табиб булып эшли. 1950 елдан Чистай шәһәрендә участок табиб-педиатры. 1951–86 да Казан мед. ин-тында, 1978 дән госпиталь педиатриясе каф. мөдире. Респ-ка пульмонология үзәген оештыручы (1982). Хезмәтләре неонатологиягә, балаларда аллергик авыруларны кисәтү һәм дәвалауга карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Характер клеточного иммунного ответа при дизентерии у детей с аллергической изменённой реактивностью организма // Казан. мед. журн. 1976. № 2.

**РОМА́НОВА** (ире ягыннан Славутская) Светлана Геннадьевна (24.12.1952, ГДР, Потсдам ш.), драма актрисасы, педагог, РФнең, ТРның халык артисты (2002, 2007). 1975 елда Чиләбе мәдәният ин-тын тәмамлый. 1975–81 дә — Чиләбе, 1981–86 да — Чита өлкә драма театрлары, 1986–95 тә М.Горький исем. Ростов акад. театры актрисасы. 1995 тән Казан Зур драма театрында. Берен-



С.Г. Р о м а н о в а Турусина («Глумов», А.Н.Островский) ролендә.



С.Г.Романова.

че рольләреннән үк труппаның әйдәп баручы актрисасы булып китә. Р.ның Персикова («Хәтәр йомыркалар», М.А.Булгаков повесте буенча), Лариса («Тавык күзе», Н.В.Коляда), Графиня («Пики дамасы», А.С.Пушкин повесте буенча; 2003 тә Чиләбе шәһәрендә узган Халыкара «Камерата-транзит» театр фестивалендә иң яхшы хатын-кыз роле өчен приз), Целия Пичем («Өч тиенлек опера», Б.Брехт), НКВД капитаны («Америка фахишәсе, яки Эчкече эти белән Россия буйлап сәяхәт», И.Квирикадзе), Гесиона («Йөрәкләр яралана торган йорт», Б.Шоу), Раневская («Чия бакчасы», А.П.Чехов; 2007 дә Самара шәһәрендә узган Бөтенроссия «Идел буе театр сезоннары» фестивалендә иң яхшы хатын-кыз роле өчен приз), Клара Цеханасьян («Дама визиты», Ф.Дюрренматт), Москалёва («Абзыкай төше», Ф.М.Достоевский повесте буенча) кебек аеруча зур рольләрендә аның нык характерга ия



С.Г.Р о м а н о в а Целия Пичем («Өч тиенлек опера», Б.Брехт) ролендә.

көчле драматик образлар иҗат итәргә сәләтле булуы ачыла. Р. иҗатына истә калырлык матур формага, рольнең тышкы зәвыклылыгына омтылыш хас. Р. әдәби эшчәнлек б-н шөгыльләнә, театр тормышындагы мөһим вакыйгаларга, ш.и. Казандагы рус театрының 210 еллыгына, СССРның халык артисты Н.И.Якушенконың тууына 100 ел, Г.Тукайның тууына 120 ел тулуга багышланган күп кенә әдәби композицияләр авторы. 1995 тән Казан Зур драма театры каршындагы Россия театр сәнгате акад. студиясендә укыта.

**РОМАНО́ВИЧ** Александр Ромуальдович (1.4.1871 — 17.11.1934, Вильно ш.), генерал-майор (1917), җәмәгать эшлеклесе. Польша-Литва татарларыннан. Полоцк кадетлар корпусын (1890), Николаев атлы гвардия уч-щесен (1892) тәмамлый. Лейб-гвардия Драгун полкында хезмәт итә, полковник (1913). Беренче Бөтендөнья сугышында катнаша. 1915 елда Калиш атлы чик буе полкы командиры. 1917 дә Финляндия чик буе дивизиясенә җибәрелә: 2 нче бригада командиры, дивизия башлыгы. 1918 дә хәрби хезмәттән азат ителә. 1918 дә Кырым крае хөкүмәтендә юстиция министры. Кырым респ-касы бетерелгәннән соң кабат Польшага кайта. Польша армиясендә хезмәт итә, Мостафа Ахматович исем. татар уланнары полкы һәм 7 нче атлы бригада командиры. 1921 дән отставкада, Вильно шәһәрендә яши. Вильно мөселманнары гминасы әгъзасы, *Речь Посполита татарларының мәдәни-агарту берлеген* оештыручыларның берсе. 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 нче, 3 нче, 4 нче дәрәҗә Изге Анна, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г р и ш и н Я.Я., Ш а р а ф у т д и н о в Д.Р. На службе Родине. К., 2005.

*Я.Я.Гришин.*

**РОМА́НОВЛАР**, бертуган Казан сәүдәгәрләре һәм җәмәгать эшлеклеләре. **Василий Иванович** (22.12.1805 — 30.10.1867, Казан) — шәһәрнең нәселдән күчмә шәрәфле гражданы, 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре. Ашлык б-н сәүдә итә, Казанда беренче буксир пароходлары, Адмиралтейство бистәсендә пар тегермәне хуҗасы. О.В.Журавлёва-Романованың вафатыннан соң яшәүдән туктаган «Казанда Романов һәм Журавлёв» сәүдә йортын оештыручыларның берсе. Казан шәһәр магистраты бургомистры, Казан шәһәр җәмәгать банкы директоры урынбасары (1848–51), Казан губернасының земство җыены әгъзасы (1867). Ул мирас итеп калдырган 15 мең акчага Александр һөнәрчеләр хастаханәсе өчен бина сатып алына. **Козьма Иванович** (1823 – 20.8.1888, Казан) — коммерция советнигы (1881 елдан), шәһәрнең нәселдән күчмә шәрәфле гражданы, 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре. Ашлык б-н сәүдә итә, Казан өязе Колсәет авылында ярма ярдыру з-ды, су тегермәне, 450 дис. җир, Зөя өязе (Казан губ.) Яр буе Морквашы авылында пар тегермәне хуҗасы. Сәүдәгәрләр старостасы (1858), Казан шәһәр магистраты ратманы (1863–66). 1870 елдан Казан шәһәр Думасы гласные, 1870–71 дә — башлыгы. Бер үк вакытта Казан өязенең земство җыены гласные (1858–76). 1884 тә Колсәет авылында, ярма ярдыру з-ды каршында һөнәр уч-щесе ача. Александр һөнәрчеләр хастаханәсенең попечителе (1869–76), анда үз акчасына 25 урынга исәпләнгән хатын-кызлар бүлеге ача; Казан реаль уч-щесе попечителе. Казан мәхкәмә округының шәрәфле җәмәгать судьясы (1868–76).

*Әд.:* А г а ф о н о в Н.Я. Казань и казанцы. К., 1906. Чыг. 1.

*Л.М.Свердлова, Е.Б.Долгов.*

**РОМАНТИ́ЗМ**, 18–19 йөзләр чигендә әдәбиятта иҗат ысулы (юнәлеше). Ул өр-яңа форма һәм эчтәлек тәкъдим итә, акыл хакимлеген кире кагып, кешедә аң төпкеле, күзаллау-хыял б-н бәйле яңа яклар ача, әдәбиятта тормышның чиксезлеген һәм кешенең эчке дөньясының байлыгын күрсәтүче геройлар тудыра дип санала. Р.ның үзенчәлекле сыйфаты — ике катлы дөнья сурәте, әдәбиятта яшәешнең реаль һәм идеаль модельләрен тудыру. Р. туууга алшартлар булып 18 йөзнең мистик-теософик тәгълиматлары, И.Гердерның тарихи-фәлсәфи концепциясе, алман классик фәлсәфәсе вәкилләре И.Кант, И.Фихте, Ф.Шеллинг, әдәбиятчылар Э.По, А.Мицкевич, Дж.Байрон, О. де Бальзак, В.Гюго, В.Скотт эзләнүләре хезмәт итә. Рус әдәбиятында Р. В.А.Жуковский һәм А.С.Пушкин исемнәре б-н бәйле.

Татар әдәбиятында Р. мөстәкыйль юнәлеш буларак 20 йөз башында С.Рәмиев, Г.Тукай, Н.Думави, С.Сүнчәләй, Г.Ибраһимов («Яшь йөрәкләр» романы, «Диңгездә», «Сөю — сәгадәт», «Карак мулла» хикәяләре), Ф.Әмирхан («Гарәфә кич төшемдә», «Кадерле минутлар» хикәяләре, «Урталыкта» романы), М.Фәйзи («Тәкъдирнең шаяруы», «Галиябану» пьесалары) һ.б. иҗатларында формалаша. Р. чоры татар әдәбиятының төп темасы милләт язмышы була. Язучылар актив рәвештә тарихка (Г.Исхакый, «Зөләйха»), легендаларга (М.Гафури, «Хан кызы Алтынчәч», Н.Думави, «Болгар кызы Тойгы туташ», Ф.Әмирхан, «Халык кызлары», Ш.Әхмәдиев, «Хан кызы») мөрәҗәгать итәләр; үз чорының тулаем бер сурәтен тергезү төп тенденция булып санала. Романтик прозаның эпик формалары (Г.Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр», «Безнең көннәр» романнары), драматик кичерешләр б-н сугарылып, психол. анализның тирәнлеге ягыннан аерылып торалар. Г.Исхакыйның «Мулла бабай» романында, «Остазбикә» повестенда халык тормышын, ислам кануннарын, руханиларны идеаллаштыру, мәхәббәткә, гаилә бәхетенә дан җырлау идиллик күренеш хасил итә. Татар романтик әдәбиятының табигате — идеал, гүзәллек, гармония дөньясы (А.Тангатаров, «Өмет», Гали Рәхим, «Серле-серле әкият» хикәяләре). Романтиклардагы мәхәббәт — кешеләрне берләштерә, явызлык һәм золымга каршы чыга (Н.Думави, «Серле тамчылар»), камилләштерә һәм рухландыра (Ш.Камал, «Ике яхшы», К.Тинчурин, «Искәндәр») торган көч. Идеал һәм реаль тормыш арасындагы каршылык герой аңы һәм күңелендә икеләнү тудыра; аның ялгызлыктан интегүе һәм идеалга сусавы әдәбиятның эсхатологик юнәлешен көчәйтә (Дәрдемәнднең «Без», «Өмид», С.Рәмиевнең «Мин үләм» шигырьләре; Ф.Борнашның «Коркыт» поэмасы, М.Хәнәфинең «Тегеннән» хикәясе һ.б.), үлем фәлсәфәсенә кайтып кала. Дошмани чынбарлыктан котылу чарасы булып табигать кочагына (Г.Ибраһимов, «Табигать балалары»), экзотик урыннарга (Г.Ибраһимов, «Диңгездә», «Табигать балалары»), балалык хатирәләренә (Дәрдемәнд, «Үткән көннәр»), хыялый дөньяга (С.Рәмиев, «Авыл»), күңел дөньясына (Г.Тукай, «Күңел»), мәхәббәт кочагына (Г.Ибраһимов, «Сөю — сәгадәт»), дингә (Г.Тукайның дини шигырьләре), үлемгә (М.Хәнәфи, «Тегеннән») качу санала.

Мәгърифәтчелек хәрәкәте милли әдәбиятта традицион символ һәм образларны, дини-суфичыл әсәрләргә хас композицион ысулларны үзгәртүгә этәргеч бирә, һәм алар үзгә контекстта кулланыла, нәтиҗәдә әсәрләрнең күпчелеге дини һәм дөньяви яссы-

лыкларда кабул ителә башлый (Г.Тукайның «И, каләм!» шигыре).

Сүз сәнгатенең милли үзенчәлеген югалтмыйча, 20 йөз башы татар шагыйрьләре һәм язучылары татар әдәбиятын Европа һәм рус әдәбиятлары үрнәгендә үзгәртергә омтылалар. Романтик әдәбиятның төп тенденциясе милләтне саклау, үстерү һәм камилләштерү була. Шәрекъ әдәбияты контекстында таныла һәм укыла торган детальләр, мотивлар, образ һәм традицион структураларны файдалану үзенчәлек кебек кабул ителә. Яңа эчтәлек яңартылган форма таләп итә башлый, бу, үз чиратында, жанрлар арасында чикләр җуелуга (мәс., хикәяне лирика б-н якынайтучы *нәсер* жанры туа) китерә. Романтизмны нәзари яктан нигезләп, Г.Гобәйдуллин, Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди татар романтик әдәбиятының шәрекъ әдәбияты б-н бәйләнешләрен сакларга омтылуын, моның, үз чиратында, әсәрләргә милли төсмер бирүен ассызыклыйлар.

1917 елдан соң романтик әдәбиятның үзгенә бәхет һәм кешеләрнең социаль тигезлеге мәсьәләсе куела (Ф.Бурнашның «Таһир-Зөһрә», М.Фәйзинең «Асылъяр» пьесалары). Иҗтимагый-тарихи вакыйгаларны тасвирлаганда авторлар дини-мифологик һәм символик образларга мөрәҗәгать итәләр (Гали Рәхимнең «Идел» повесте; Һ.Такташның «Җир уллары трагедиясе» һәм шигырьләре).

Р. традицияләре татар поэзиясендә 20 йөз дәвамында үзен сиздерә. Бу чор Р.ында шартлы рәвештә капма-каршы 2 агым — оптимистик һәм пессимистик агымнарны бүлеп чыгаралар. Беренчесенә бөтен тереклек дөньясына мәхәббәт, якты киләчәккә өмет, яхшылыкның җиңәчәгенә ышаныч хас. Кеше һәм җәмгыятьне камилләштерү мөмкинлеге геройга үз эчке каршылыкларын җиңәргә көч бирә. Ул үз чоры проблемаларын хәл итү өчен көрәшә, идеалын киләчәктә таба һәм шул якты киләчәкне якынайтырга тели. Мәс., Р.Гатауллин (Гаташ) иҗатындагы күпсанлы метафоралар һәм хисләрнең бер чиктән икенчесенә ташлануы иң югары кыйммәт итеп мәхәббәтне тануга хезмәт итә. Пессимистик Р. дөньяны үзгәртү мөмкин түгеллеген аңлаган, реаль чынбарлыктан хыял-фантазия дөньясына китеп барган, идеалны үткәннәрдә генә күргән герой тудыра. И.Юзеевнең мифология б-н сугарылган иҗатында романтик геройның катлаулы күңел кичерешләрен, бай һәм тирән рухи дөньясын бирүгә омтылыш яшәеш мәсьәләләренә җиһан масштабында мөрәҗәгать итүгә сәбәп була.

20 йөз ахырында сәнгати формаларны яңартуга йөз тоткан неоромантизмда Р. үзенең үсешенә яңа этәргеч ала. Җәмгыять кануннарына буйсынып яшәргә сәләтсез романтик герой туа (М.Вәлиев, «Качу» повесте). Ике катламлы дөнья башкаларны яратуга сәләтле булу һәм үзеңне ярату (эгоизм) каршылыгында хасил була (Ф.Садриев, «Кыргый алма әчесе» повесте). Бу ике төрле тормыш моделе укучыны, башкалар мәнфәгатен хөрмәт иткән кешеләр тирәлек һәм үз-үзләре б-н гармониядә яши, дигән фикергә китерә. 20 йөзнең 2 нче яртысында Р. традицияләренә беренчеләрдән булып М.Галиев мөрәҗәгать итә: аның «Ак абагалар» һәм «Алтын тотка» повестьларына лиризм һәм тирән фәлсәфә хас. Мәхәббәт һәм иҗади илһам турында сөйләгәндә, автор тарихны — чынбарлыкка, рухи кыйммәтләрне матди кыйммәтләргә каршы куя.

20 йөз ахырында реалистик һәм романтик агымнар кушылып китә. Мәсәлән, М.Кәбировның «Мәхәббәттән җырлар кала» повесте укучы игътибарын урта гасыр Шәрекъ әдәбияты өчен традицион сөю мотивына юнәлтүче аллюзиягә әйләнә. Повесть бәхетсезлек б-н тәмамлануга карамастан, фаҗига эмоциональ өстенлек алмый, аны мәхәббәтнең чиксез көченә ышану б-н бәйле якты хис җиңә.

20–21 йөзләр чигендә гадәти булмаган мәхәббәт тарихы милләтара конфликтларның, техноген катастрофалар, сугышларның фаҗигале тарихы б-н үрелеп китә торган повестьлар языла (Ә.Сәлаховның «Соңгы вальс», Р.Бәшәрнең «Адашкан кош тавышы», «Акбалык» повестьлары). Романтик повестьлар тукымасына бик табигый төстә тирәлекне сызланып (экзистенциаль) кабул итү принциплары урнаша һәм алар әсәрләрнең кыйммәти юнәлешен үзгәртә. Ш.у.к. *Гыйсъянчылык*.

*Әд.:* Г а н и е в а Р.К. Совет чорындагы әдәбиятларында иҗат методы мәсьәләләре. К., 1988; З а һ и д у л л и н а Д. Дөнья сурәте үзгәрү. К., 2006; Н и г м а т у л л и н а Ю.Г. Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. К., 1997; Теория литературы. Т. 4. Литературный процесс. М., 2001; З а р и п о в а - Ч е т и н Ч. Проблема демонизма в творчестве С.Рамиева в контексте восточно-европейской эстетики. К., 2003.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**РОМА́НЫЧЕВ** Михаил Иванович (29.11.1923, Тәтеш кантоны, хәзер Тәтеш р-ны Зеленовка а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1983). Тәтеш а.х. техникумын (1945), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1960) тәмамлый. 1939–48 елларда Тәтеш р-нында: МТСта слесарь, агроном, КПСС район к-ты инструкторы (1947 дән). 1948–85 тә Лаеш р-нында: Иске Пристань посёлогында җидееллык мәктәп директоры, КПССның район ком-тының оештыру бүлеге мөдире (1956 дан), «Комсомольский» с-зында партком секретаре (1957 дән), директор (1962 дән). Р. җитәкчелек иткән елларда совхозда һәр сыердан еллык савым 1825 *кг* нан 3660 *кг* га кадәр, бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 5,7 *ц* дан 17 *ц* га кадәр арта, а.х. продукциясенең барлык төрләрен җитештерүдә хезмәт чыгымнары кими. Елына 500 *т* кош ите җитештерә торган фабрика, 200 башка исәпләнгән бозаулар торагы, 4200 *м*² торак, 2 клуб, балалар бакчасы, ашханә, хастаханә, мунча төзелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә.

**РОМА́ШКА**, б а б ү н ә (Matricaria), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан берьеллык үлән чел үсемлекләр ыругы. 70 кә якын төре билгеле, Евразиядә, Африкада таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — дару ромашкасы (M. recutita) бар. Барлык районнарда да очрый. Буш, кысыр җирләрдә, чүп урыннарында, юл буйларында үсә. Нәзек, үзәк тамырлы. Сабагы туры, ботаклы, 10–30 *см* биеклектә. Яфраклары чиратлашкан, икешәр каурыйсыман-теленмә. Чәчәкләре озын чәчәк сапларында утырган калкан чәчәк төркеме хасил итүче кәрзиннәрдә урнашкан. Кәрзиннәр озынча конуссыман чәчәк түшәгеннән гыйбарәт, эче куыш (шушы билгесе буенча дару ромашкасы башка охшаш төрләрдән җиңел аерыла). Чәчәкләре һәрбер кәрзиндә ике типта: кырыйдагылары — телсыман, ак таҗ яфракчыклы ана чәчәкләр; уртадагылары — көпшәсыман, сары, ике җенесле. Җимешләре — бүрекчәсез коңгырт-яшел вак орлыкчалар. Үсемлекнең үзенчәлекле исе бар. Июньнән сентябрьгә кадәр чәчәк ата. Җимешләре августта өлгерә. Орлыктан үрчи. Дару үсемлеге. Чәчәк кәрзиннәрендә эфир мае, флавоноидлар, гликозид, лайлалы матдәләр бар; дезинфекцияләү, тир чыгару, ялкынсынуга каршы, авыртуны басу чаралары буларак кулланыла. Тынычландыру, ашказаны җыелмалары составына керә. Чәчәк төркеме косметик чаралар әзерләүдә файдаланыла.



Дару ромашкасы.

**РОМА́ШКИН** Алексей Акимович (1920–1985, Мәскәү), генерал-майор (1961), хәрби фән. канд. (1960). Бөек Ватан сугышында катнаша. Ф.Э.Дзержинский исем. Хәрби академияне (Мәскәү, 1955) тәмамлый, шунда ук эшли (1960 елга кадәр). 1960–63 елларда Стратегик максатлардагы ракета гаскәрләренең урта училищесе башлыгы (Мәскәү өлкәсе Серпухов ш.). 1963–74 тә Казан югары хәрби инженер-комндирлар уч-щесе башлыгы. Р. 194 лаборатор җайланманы проектлау һәм эшләү, 14 хәрби лаб. оештыру б-н җитәкчелек итә. 1974 тә аның тырышлыгы б-н уч-щегә адъюнктура кертелә. Хезмәтләре стратегик максатлардагы ракета гаскәрләре берләшмәләре һәм частьларының хәрәкәт тактикасына карый. 1975 тән отставкада. Ике Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденлары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Тактика действий соединений и частей ракетных войск стратегического назначения. М., 1958; Методика преподавания специальных дисциплин в Высшем военном учебном заведении. М., 1967.

*М.З.Хәбибуллин.*

**РОМА́ШКИНА** Гөлнара Фатих кызы (8.2.1962, Казан), социолог, физика-матем. фән. канд. (1990), социол. фән. д-ры (2003), проф. (2004 тән). Казан ун-тын тәмамлаган-

нан соң (1984), Төмән архит-ра-төзелеш академиясенең материалларның каршы торучанлыгы кафедрасында эшли. 1995 елдан Төмән нефть-газ ун-тының гамәли математика һәм информатика, 2003 тән Төмән ун-тының икътисади социол. кафедраларында. Хезмәтләре идарә итү социологиясенә, икътисадта һәм социологиядә матем. ысуллар һәм модельләргә, конфликтологиягә багышлана.

Х е з м.: Моделирование в системе управления социальными процессами. Тюмень, 2002; Математические модели социальных процессов. Тюмень, 2005; SPSS в социологических исследованиях: Учеб. пособие. Тюмень, 2009 (автордаш).

**РОМА́ШКИНО НЕФТЬ ЧЫГАНАГЫ́**, Бөгелмә шәһәреннән көнбатыштарак; дөньядагы иң зур 10 чыганакның берсе. 1948 елда хәзерге Лениногорск р-нының Тимәш авылы кырыенда 3 нче скважина б-н ачыла, бу урында истәлек стеласы куелган. 1952 дә гамәлгә кертелә. 1973 тә Р.н.ч. составына 1943 тә ачылган Шөгер нефть чыганагы кертелә. Ромашкино күтәрелешенә туры килә, 1934 тә Е.И.*Тихвинская* җитәкчелегендә Татарстан геологлары тарафыннан Пермьнең Казан утырмалары буенча картага төшерелә, соңрак тагын да борынгырак структур бораулау б-н раслана. Сәнәгый ятмалар девон (80%) һәм карбон утырмаларында; ятмаларның уртача тирәнлеге 600–1800 *м*. Скважиналарның башлангыч дебиты тәүлеккә 300 *т* га кадәр, нефтьнең уртача тыгызлыгы 0,8–0,86 *г/см*³, күкерт 1,05–4,6%, парафин 3,8–5,1%. Чыганакта 22 нефть горизонты, шуның 18 ендә сәнәгый нефть. Зур күләмле һәм катламлы-гөмбәзсыман 400 дән артык ятма билгеләнгән. Терриген коллекторлар — катламланган комсу, алевролит һәм аргиллит токымнардан, карбонат коллекторлар известьташ һәм доломитлардан тора. Тыгызлыгы буенча җиңел (терригенлы девон) һәм авыр (карбон) нефтькә бүленә, нефтьнең авырлашуы астан өскә таба бара. Девонга караганда карбон нефтендә күкерт һәм кокс 2 тапкыр күбрәк; алар үзлерәк, газның күләме азрак.



3 нче номерлы скважина – Ромашкино чыганагында нефтьне сәнәгый чыгару буенча беренче скважина.

Сумала һәм асфальтеннарның күләме киселеш буенча өскә таба артуы б-н бер үк вакытта парафин һәм аксыл фракцияләрнең кимүе бара. Көнбатыштан көнчыгышка һәм көньяктан төньякка таба девон нефтендә күкерт һәм сумаланың күләме арта. Углеводород составы буенча нефтьләр метан-нафтенлы типта.



Нефть чыганагын ачу һәм үзләштерүдә катнашучыларга һәйкәл. 1998. Лениногорск районы Тимәш авылы янында.

Р.н.ч.нда төп эшкәртү объектлары булып $Д_1$-$Д_0$ һәм Бобрики горизонтлары тора. Девонның терриген утырмаларында 19,5 меңнән артык скважина бораулаган. Еллык макс. чыгарылышы 81,5 млн. *т* (1970), 6 ел дәвамында 80 млн. *т* дәрәҗәсен тота, 1999 га 11,1 млн. *т* га кадәр кими. Бобрики горизонты утырмаларында 13 нефть ятмасы билгеләнә; макс. нефть чыгышы 1980 дә — якынча 7 млн. *т* (карбон), 1999 да 2,9 млн. *т* га төшә. Нефть чыгару суэтем юлы б-н катлам басымы режимында алып барыла. 60 ел эчендә Р.н.ч.нда 2,2 млрд. *т* нефть чыгарыла, шуның 90% тан артыгы — девон утырмаларыннан.

*Әд.:* М у с л и м о в Р.Х. Освоение супергигантского Ромашкинского месторождения — выдающийся вклад учёных и специалистов России в мировую нефтяную науку и практику разработки нефтяных месторождений // Георесурсы. 2008. № 4.

*Р.Д.Габделмәҗитов, Г.Г.Емельянова.*

**«РОМА́ШКИНСКИЙ»**, Чистай р-нындагы совхоз. 1965 елда «Каргалы» с-зын бүлү нәтиҗәсендә оештырыла. Үзәк утары — Татар Сарсазы авылы (1976 елга кадәр Иске Ромашкино а.). А.х. файдалануы җирләренең мәйданы 3414 *га*, ш.и. сөрүлек җирләр — 3313 *га*. Эшләүчеләр саны 212 кеше. Хуҗалыкның төп юнәлеше — дуңгыз үрчетү. 1981–95 тә дуңгызлар саны 19–22 мең баш тәшкил итә. 100 *га* а.х. файдалану җирләренә 1981–85 тә уртача 1384 *ц* ит, 1986–90 да 1233 *ц* ит җитештерелә. Хуҗалык эшчеләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 3 кешегә ТАССР, ТРның атказ. хезмәткәре исеме; 1 кешегә Халыклар дуслыгы ордены, 1 кешегә 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны ордены, 1 кешегә медаль бирелә. 1997 дә совхоз «Р.» дәүләт унитар пр-тиесе итеп үзгәртелә.

Хуҗалыкның җитәкчеләре — И.Ш.Идиятуллин (1967–70), Г.Р.Назаров (1981–85), И.Г.Галиев (1985–96), Р.А.Урманчеев (1996 дан).

**РОМБЛЫЛА́Р**, кандалаларның берничә үзара якын семьялыгы (Coreidae, Alydidae, Rhopalidae, Stenocephalidae). Нигездә, уртача зурлыкта яки зур (5–18 *мм*), гәүдәсе тыгыз капламлы, гадәттә, коңгырт төстә. Корсагы еш кына ромбсыман, кырыйлары өске канатлары б-н капланмаган. Күбесенчә кузаклылар, оешма чәчәклеләр, кыяклылар һ.б. үсемлекләрнең генератив органнарының согы б-н туена. Күп кенә төрләре люцернаны зарарлый. Кайбер төр Р. личинкаларының үзенчәлекле саклану ысулы бар: куркыныч килгәндә, алар аркаларын исле биз сыекчасы б-н юешлиләр; биз сыекчасы парга әйләнә, һәм бөҗәкләр саклану тышчасы б-н капланган кебек булалар. Татарстан терр-ясендә 80 гә якын төре бар. Бөтен җирдә диярлек таралганнар. Кузгалак кандаласы (Coreus marginatus) — гадәти төр, озынлыгы 12–15 *мм*, кузгалакта һ.б. карабодайчаларда яши.

*А.В.Беспятых.*

**РОМОДА́Н** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Актай елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 15 *км*, бассейнының мәйданы 119 *км*². Идел аръягы түбәнлегеннән, Алексеев р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Ромодан авылыннан 7 *км* көнчыгыштарак, тамагы Гурьевка авылында. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы — 77 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Р.ның 2 дән 8,8 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар; иң зурысы — Шкимер (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,3 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 85 *мм*, ташу вакытында су катламы 57 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,115 *м*³*/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Елгада суның гомуми күләме 0,6 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**РОМОДА́Н** (Рамодан) авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ромодан елгасы буенда. 2010 елда 381 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 75%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 гә кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богородский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Смоленск Богородица чиркәве (1779 да төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1883 тә ачыла), фельдшерлык пункты, телефон станциясе, вак кредит учреждениесе; 1 — пар, 3 — су һәм 2 җил тегермәне, 3 ярма яргыч, 5 тимерче алачыгы, 1 йон тетү йорты, 3 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 7 вак-төякләр кибете була; сишәмбе көн-

нәрендә базар эшли. Бу елларда авыл җәмәгатенең имана җире 2633 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Ромодан волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1935 нең 25 гыйнварыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 271 ир-ат; 1859 да — 1114, 1897 дә — 1387, 1908 дә — 1505, 1920 дә — 1787, 1926 да — 1292, 1938 дә — 873, 1949 да — 578, 1958 дә — 628, 1970 тә — 402, 1979 да — 407, 1989 да — 468, 2002 дә — 440 кеше.

**РОМОДА́Н РАЙОНЫ́**, *Мордва Республикасының* үзәгендә урнашкан. 1928 елның 16 июлендә оештырыла. Мәйданы — 820,8 *км*². Үзәге — шәһәр тибындагы Ромоданово посёлогы (Саранскидан 30 *км* төньяктарак). Халкы — 20067 (2013), татарлар — 4367 (2010) кеше. Татарлар, нигездә, Ләбәҗә (Алтары) (1026 кеше), Азюрка (Белозерье) (2934) авылларында, район үзәгендә (359) яшиләр. Ләбәҗә һәм Азюрка авылларын 17 йөз уртасында рус хөкүмәте Атемар чик буе киртәләренә күчергән Темников йомышлы татарлары нигезли. 1917 гә кадәр Р.р.нда 5 мәчет (2 се — Ләбәҗәдә, 3 се — Азюркада), берничә мәдрәсә һәм мәктәп эшли. 1896–98 дә Ләбәҗә авылы мәдрәсәсендә (1888 нең 23 сентябрендә ачыла) татар язучысы Ш.*Камал* укый. 1902 дә ике класслы земство мәктәбе эшли башлый, Совет хакимияте чорында ул 1 нче баскыч төрки-татар совет мәктәбе итеп үзгәртелә. 1930 елларда, Ләбәҗәдәге мәчеттән кала, райондагы барлык мәчетләр дә ябыла. Хәзерге вакытта Р.р.нда 9 мәчет бар, шуларның 7 се — Азюркада (1 мәчет 1989 дан, 3 се — 2001 дән, 2 се — 2002 дән, 1 се — 2004 тән), 2 се — Ләбәҗәдә (1888 һәм 1995 тән). Төбәк тарихы музее, үзешчән сәнгать коллективы (Ләбәҗә а.), «Яшьлек» фольклор-бию ансамбле (Азюрка а.) эшли. Азюрка авылы урта мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла. ТР ФА һәм РМА академигы М.И.*Мәхмутовның* (Ләбәҗәнең бер урамы аның исемен йөртә), мед. фән. д-ры Р.З.*Ашировның*, биол. фән. д-ры О.Ж.*Курмаевның* тормышлары һәм хезмәт эшчәнлекләре Р.р. б-н бәйле.

**РОМОДА́НОВСКИЙ** Юрий Иванович (1632 тирәсе — 16.5.1683, Мәскәү), кенәз, хәрби һәм дәүләт эшлеклесе. Стольник (1648), бояр (1655). Патша Алексей Михайловичның көрәштәше, гомеренең күп өлешен сарай каршында йөкләмәләр үтәп уздыра. 1654–55 елларда Польша б-н сугышта патша полкы есаулы. 1667–73 тә Пушкарский приказ судьясы (җитәкчесе). 1673–76 да Казанда 1 нче воевода.

*Е.В.Липаков.*

**РО́ОТ** Андрей Александрович (22.12.1927, Казан), журналистика өлкәсе галиме, филол. фән. д-ры (1995), проф. (1996), атказ. фән эшлеклесе (1997). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1957), Казан мәктәпләрендә укыта. 1965 елдан Казан ун-тында, 1992–97 дә рус журналистикасы каф. мөдире. «*Тонус*» альманахы баш мөхәррире (1996 дан). Хезмәтләре рус журналистикасы тарихы һәм рус эмигрантлары матбугатына карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Типология передовых статей Герцена в «Колоколе». К., 1974; История жанра передовой статьи. К., 1980; «Колокол» возрождённый. К., 1989; Традиции Вольной русской прессы. К., 1992.

**РО́РЛИХ** Азаде Айша (25.4.1942, Констанца ш., Румыния), тарихчы, тарих д-ры (1976). 1960 елларда Бухарест ун-тында укый, рус теле һәм әдәбиятын өйрәнә. АКШка күченеп килгәннән соң, 1972 дә Висконсин ун-тында (Мадисон ш.) рус тарихы магистры дәрәҗәсен ала. 1976–77 дә Көнбатыш Иллинойс ун-тында (Макомб ш.). 1977 дән Көньяк Калифорния ун-тында (Лос-Анджелес ш.). Хезмәтләре Идел буе, Урал татарлары һәм мөселманнары тарихына карый. «The Volga Tatars: A Profile in National Resilience» («Милли тотрыклылык күзлегеннән Идел буе татарлары», Стэнфорд, 1986) китабында тарих белемендә беренче тапкыр татарларның этнос формалашудан алып бүгенге көнгә кадәр үсеше өйрәнелә. И.*Гаспринский* хатларын басмага әзерли (Ismail Gasprali. French and African Letters. Ist., 2008).

Х е з м.: Komunist Idaresinde Volga-Ural Müslümanları. Ankara, 1984; Volga Tatarları Yüzyılları Aşan Milli Kimlik. Ist., 2000.

**РО́СКИН** Борис Залманович (30.1.1914, Витебск губ. Велиж ш. — 29.12.1999, Казан), драма актёры, педагог, ТАССРның атказ. артисты (1968). 1931–33 елларда — Ленинград ун-тының эшчеләр ф-тында, бер үк вакытта профсоюзларның Ленинград өлкә советы театры каршындагы студиядә укый, соңгысын 1935 тә тәмамлый. 1934–37 дә — Ленинград



Б.З.Р о с к и н Подхалюзин ролендә («Агай-эне — ак мыек», А.Н.Островский).

драма театрлары, 1937 дән Сталинград, Калинин, Ростов-Дон яшь тамашачылар театрлары актёры. 1942 дә Сталинград яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) труппасы б-н берлектә Казанга җибәрелә. 1942–80 дә Казан яшь тамашачылар театрының (ТЮЗ) әйдәп баручы актёрларыннан берсе, аның сәхнәсендә 200 гә якын роль башкара, иҗатында Ленинград мәктәбе принципларына таяна: рольнең тышкы күренешен эчке чынлык һәм психологизм берлегендә камиллеккә ирештерү. Р.ның яшь геройлары — югары сыйныф укучылары, студентлар, эшчеләр: Ваня («Әкият», М.А.Светлов), Ганичев («Студентлар», Б.Дьяков, М.Пенкин), Гера Коробов («Өлгергәнлек аттестаты», Л.Б.Гераскина), Петя Яковлев, Костя Полетаев («Аның дуслары», «Тормыш сәхифәсе», В.С.Розов) һ.б. Алар үз-үзләрен тотышлары, зыялылыклары, бай рухи дөньялары б-н аерылып торалар. Аның тарафыннан иҗат ителгән Пётр («Мещаннар», М.Горький), Лещинский («Корыч ничек чыныкты», Н.А.Островский романы буенча), Кулыгин («Өч сеңел», А.П.Чехов) образлары социаль характеристиканың төгәллеге ягыннан билгеләп үтелә. Подхалюзин, Кнуров, Мамаев («Агай-эне — ак мыек», «Бирнәсез кыз», «Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр», Н.А.Островский), Бобчинский («Ревизор», Н.В.Гоголь), фон Кальб («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер) рольләрендә характерның чын асылы ачыла. Р.ның Ромашов («Ике капитан», В.А.Каверин романы буенча), Аркадий, Пётр Аверин («Хәерле сәгатьтә!», В.С.Розов), Яков Коломийцев («Соңгылар», М.Горький), Суворов («Бер мәхәббәт тарихы», А.Тоболяк повесте буенча) образлары рольнең тышкы басынкылыгы артында психол. анализ тирәнлеге яту б-н үзенчәлекле. Р. татар драматурглары пьесалары буенча да күп кенә рольләрне сәнгатьле итеп башкара: Юныс бай («Тапкыр егет», Д.Аппакова), Сәмигулла («Умырзая чәчәкләре», Ю.Әминев), Кәбир Галимуллин («Гадәттән тыш вәкаләтле вәкил», Н.Исәнбәтнең «Мулланур Вахитов» пьесасы буенча). Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) сәхнәсендә «Якын илләргә сәяхәт» («Путешествие в ближние страны», Л.А.Малюгин), «Ә Алёшка белән без дуслар» («А с Алёшкой мы друзья», Г.С.Мамлин) спектакльләрен куя. Казан яшь тамашачылар театры каршындагы студиядә һәм һәвәскәрләр театры коллективында пед. эшчәнлек алып бара; шәкертләре арасында Э.Г.*Җиһаншина*, Н.М.*Кочнева* бар.

*Әд.:* Б л а г о в Ю.А. Казанский театр юного зрителя (Очерк истории). К., 1986.

*Ю.А.Благов.*

**РОССИ́Я**, к. *Россия Федерациясе; Россия империясе.*

**«РОССИ́Я ДӘҮЛӘТЕ́ ТӨРКИ́-ТАТА́Р ХАЛКЫНА́»**, КОМУЧ мөрәҗәгате. Учредительләр җыены әгъзалары ком-тының 1918 ел 8 сентябрь мөрәҗәгатендә төрки-татар халкының милли-мәдәни мохтариятккә хокукы КОМУЧ тарафыннан бәхәссез дип танылу турында игълан ителә: төрки-татарларга җирле идарә, үзидарә эшчәнлеген, мәхкәмә эшен туган телләрендә алып бару, ирекле рәвештә мәктәпләр ачу, дини тормышларын мөстәкыйль рәвештә кору хокукы бирелә; алар закон нигезендә мәҗбүри буйсындырулы көчкә ия халык хакимияте, махсус милли салымнар билгеләү һәм җыю, мәдәният, икътисад, җәмәгать тәрбиясе һәм халык мәгарифе мәсьәләләрен мөстәкыйль рәвештә хәл итү вәкаләте булган милли үзидарә органнары төзи алалар. Мөрәҗәгать «Вестник Комитета членов Всероссийского Учредительного Собрания» г-тасында басылып чыга.

*Әд.:* Садри Максуди Арсал. Конституция Культурно-национальной автономии татарского народа // Идель. 1995. № 5/6.

**РОССИ́Я ИКЪТИСА́Д УНИВЕРСИТЕТЫНЫ́Ң КАЗА́Н ИНСТИТУТЫ́** (филиал) Г.В.Плеханов исем. югары уку йорты. 1954 елда СССР Сәүдә министрлыгы әмере б-н Бөтенсоюз совет сәүдәсе читтән торып уку ин-тының ф-лы буларак оештырыла. 2012 нең декабренә кадәр Россия сәүдә-икътисад ун-ты (РГТЭУ) структурасына керә, соңгысын үзгәртеп оештырганнан соң, РГТЭУның элеккеге Казан ин-ты (ф-лы) да Г.В.Плеханов исем. Россия икътисад ун-тының Казан ин-ты (ф-лы) итеп үзгәртелә. 2012 гә кадәр ф-лда читтән торып уку формасы гына алып барыла. 2015 тән Казан ун-ты составына керә. 1995 кә кадәр — көндезге һәм читтән торып уку бүлекләрендә белгечләр өч юнәлеш (менеджмент, икътисад, коммерция); 1996 дан менеджмент, бухгалтерлык исәбе һәм аудит, коммерция, дөнья икътисады, пр-тие икътисады һәм идарә итү (сәүдәдә) буенча әзерләнә. 2011 дә гамәли информатика һәм сервис белгечлеге ачыла. Исәп-хисап, финанс һәм банк эше; менеджмент; дөнья икътисады; коммерция; гуманитар фәннәр; чит телләр; информатика һәм югары математика кафедралары эшли. Эшләү дәверендә 30 меңнән артык белгеч әзерләнә. Тәмамлаучылар арасында Р.Н.Миңнеханов, Р.Ф.Моратов бар. Укытучылар коллективында — 92 кеше, ш.и. 11 фән. д-ры, 66 фән канд. (2013). Институт директорлары: Д.В.Наумова (1954–61), А.М.Леонтьев (1961–79), В.П.Сидоров (1979–84), Р.Х.Акбашев (1984–2004), Г.Р.Хәмидуллина (2004–06), Р.Б.Хәйруллин (2006–10), А.В.Артемьев (2010 нан).

**РОССИ́Я ИМПЕ́РИЯСЕ** (Россия), күпмилләтле дәүләт (1721–1917). Терр-ясе 22,4 млн. *км²*; халкы — 128,2 млн. кеше (19 йөз ахыры), 100 дән артык милләтне берләштерә. 81 губернага (ш.и. *Казан губернасы*), 20 өлкәгә бүленә (1914), 931 шәһәре була. Р.и.ндә монархия тәртибе хөкем сөрә. Дәүләт башында хокукы чикләнмәгән, хакимиятне нәсел буенча тапшырган монарх-император тора. Ул законнар чыгару буенча хакимлеген Дәүләт Советы (1810 елдан — Р.и.нең законнар чыгару-киңәшмә органы, 1906 дан — югары законнар чыгару палатасы) һәм *Дәүләт Думасы* (1906 дан) аша тормышка ашыра; дәүләт аппараты б-н җитәкчелекне Сенат (1711 дә гамәлгә кертелә; 19 йөздә югары күзәтчелек һәм мәхкәмә органы), Министрлар советы һәм министрлыклар аркылы башкара; Р.и. Кораллы Көчләре Югары башкомандующие булып тора; Синод аша чиркәү эшләре б-н идарә итә. Дәүләт гербы — патша хакимлеге регалийлары төшерелгән ике башлы бөркет; дәүләт флагы — ак, зәңгәр һәм кызыл төстәге горизонталь буйлы тукыма; дәүләт гимны — «Боже, царя храни»; дәүләт теле — рус теле. Империя халкы дүрт сыйныфка бүленә: дворяннар (сәяси хакимияткә ия өстенлекле катлау), руханилар, шәһәр халкы (шәрәфле гражданнар; сәүдәгәрләр; мещаннар яки бистә кешеләре; һөнәрчеләр яки цех тотучылар), авыл халкы (крәстияннәр).

14 йөздә — 16 йөз уртасында Төньяк-Көнчыгыш һәм Төньяк-Көнбатыш Русь җирләрен берләштергән Рус дәүләте барлыкка килә. Р.и.нә 16 йөзнең 2 нче яртысында *Казан ханлыгын* (к. *Казанның яулап алынуы, Казан җирләрендә азатлык сугышлары (1552–56)*), *Әстерхан ханлыгын* һәм *Себер ханлыгын* яулап алу аша нигез салына. 17–19 йөзләрдә Россия составына Украина, Балтыйк буе, Белоруссия, Төньяк Кавказ, Кырым (к. *Кырым ханлыгы*), Бессарабия, Польшаның күпчелек өлеше (Польша патшалыгы), Финляндия, Кавказ арты, Урта Азия кертелә. 1721 елда Россия рәсми рәвештә империя дип игълан ителә. 17 йөз ахырында — 18 йөзнең 1 нче чирегендә *Пётр I* идарә итүдә, хәрби эш, сәнәгать һ.б. өлкәләрдә илне икътисади һәм мәдәни яктан интенсив үсешкә китерәчәк реформалар уздыра. Социаль-икътисади изү, милли һәм дини кысуларның көчәюе 17 йөздә — 18 йөзнең 1 нче чирегендә *башкорт-татар кузгалышларына* китерә, *Батырша хәрәкәтенә* (1755–56), *Крәстияннәр кузгалышына* (1773–75) сәбәп була. 18 йөзнең 2 нче яртысында патша хөкүмәте *татарлар турында Россия канунчарына* үзгәртүләр кертә, рус булмаган халыкларны *христианлаштыру сәясәтен* йомшарта. 1812 елгы *Ватан сугышында* Россия Наполеон агрессиясен кире кайтара. Сугыш хәрәкәтләрендә *Казан ополчениесе, татар-башкорт атлы полклары* катнаша. *Крәстиян реформасы (1861)* барышында *крепостнойлык хокукының* бетерелүе һәм 1860–70 еллардагы башка реформалар Россиядә *капитализмның* алга таба үсеше өчен алшартлар тудыра. Казан губернасы *крәстияннәре* патша хөкүмәтенең җир мәсьәләсен хәл итү карарына *Бизнә крәстияннәре кузгалышы* һ.б. чыгышлар б-н җавап бирә. Россиянең алга таба үсеш юлларын эзләү *народниклык* хәрәкәтен китереп чыгара (к. *«Народная воля»*). 19 йөз ахырында — 20 йөз башында сәяси партияләр (РСДРП, *Социалист-революционерлар партиясе, Конституцион демократлар партиясе, «Унҗиденче октябрь берлеге», «Иттифакъ әл-мөслимин», «Рус халкы берлеге»* һ.б.) һәм *профсоюзлар* барлыкка килә. 20 йөз башында социаль-сәяси каршылыклар кискенләшү *Россиядә 1905–07 еллар революциясенә* китерә. Монархиячел хакимият Дәүләт Думасын оештырырга мәҗбүр була, крәстиян җир иманалары реформасын (к. *Столыпинның аграр реформасы*) тормышка ашырырга керешә. Россия *Беренче бөтендөнья сугышында* катнаша. 1917 елгы *Февраль революциясе* вакытында монархия тәртибе юкка чыгарыла. 1917 нең 2 мартында император Николай II тәхеттән ваз кичә. 1917 нең 1 сентябрендә Вакытлы хөкүмәт Россияне респ-ка дип игълан итә.

*Әд.:* Геллер М.Я. История Российской империи. М., 1997. Т. 1–3; Каменский А.Б. Российская империя в XVIII веке: традиции и модернизация. М., 1999; Миронов В.Б. Российская империя XIX – начала XX века. М., 2011.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**РОССИ́Я ИСЛА́М ИНСТИТУТЫ́**, Казандагы дәүләтнеке булмаган югары уку йорты. 1998 елда Россия ислам ун-ты буларак ачыла. Оештыручылары — Россия Мөфтиләр шурасы, ТР мөселманнары Диния нәзарәте, ТР ФАнең Ш.Мәрҗани исем. Тарих ин-ты. Дин эшлеклеләре, мөселман уку йортлары өчен укытучылар һәм башка дөньяви югары белемле белгечләр әзерли. Институт составында — теология, лингвистика (гарәп һәм инглиз телләре), дөнья икътисады, журналистика бүлекләре эшли. 2006 дан дини ф-т аерым уку йорты — Казан ислам ун-ты буларак бүленеп чыга. Ин-тта укыту РФ Дәүләт стандартлары буенча алып барыла, дәүләт үрнәгендәге дипломнар бирелә. Укыту рус, татар һәм гарәп телләрендә алып барыла.



Россия ислам институты.

2015/16 уку елына ТРдан һәм РФнең 38 төбәгеннән 1200 студент, ш.и. 400 хатын-кыз укый; пед. коллективта 80 кеше эшли, ш.и. 8 фән д-ры һәм 28 фән канд-ты. Дин фәннәрен укытучылар арасында Мисыр, Төркия, Иордания, Малайзия, Сүрия һ.б. илләрнең ислам ун-тларында белем алган Россия белгечләре бар. Махсус курсларны укыту өчен, Казан, Мәскәү, С.-Петербург югары уку йортларыннан һәм фәнни учреждениеләреннән әйдәп баручы галимнәр — шәрекъ телләре белгечләре чакырыла. Беренче ректоры — ТР мөфтие Г.Г.*Исхаков* (1998–2005); 2005–06 да — И.К.Заһидуллин, 2006 дан — Р.М.*Мөхәммәтшин*.

**РОССИ́Я МӨСЕЛМА́Н ҖӘМӘГА́ТЬ ОЕШМАЛАРЫНЫ́Ң МӘРКӘ́З (ҮЗӘ́К) КОМИТЕТЫ́.** Мөселман җәмәгать оешмалары вәкилләре корылтае карары б-н 1914 елның декабрендә оештырыла. Максаты — яралы мөселман сугышчыларына ярдәм оештыруны координацияләү. Рәисе — И.Ә.Әхтәмов, әгъзалары — С.Алкин, Ә.Н.Максудов, Г.Ш. һәм Ш.Ш.Сыртлановлар, К.Тәфкилев, З.Шамил һ.б. (барлыгы 28 кеше). Ком-т лазаретлар ачу, сан. отрядлар оештыру, саклану урыннары төзү һ.б. б-н шөгыльләнә. 1917 елгы вакыйгалардан соң эшчәнлеге туктатыла.

**РОССИ́Я МӨСЕЛМА́Н КОММУНИСТЛАРЫ́ ПА́РТИЯСЕ** (РМКП). Шундый оешма булдыру фикере беренче тапкыр Россия мөселман эшчеләренең 1918 елның 8–28 мартында узган конференциясендә (Мәскәү) алга сөрелә. Конференциядә катнашучылар, Б.*Мансуровның* докладын тыңлаганнан соң, мөселман социалистлар-коммунистлар партиясе төзелү турында белдерәләр. 1918 нең июнь урталарында Казанда көн тәртибенә Казан мөселман социалистлар ком-ты

составында коммунистлар фракциясе оештыру мәсьәләсе куелган киңәшмә үткәрелә, анда булачак партиянең структураларын формалаштыру буенча беренче адымнар ясала, коммунистлар фракциясенә яңа әгъзалар кабул итү кагыйдәләре раслана, фракциянең рәисе (А.Касппранский-Измайлов) һәм секретаре (К.Саттаров) сайлана. Мөселман коммунистларының мөстәкыйль оешмасын төзү буенча төп карар Казан, Мәскәү, Петроград, Архангельск, Пермь, Самара, Саратов, Сембер, Урал мөселман революцион оешмалары вәкилләре киңәшмәсендә (1918 нең 17–23 июне, Казан) кабул ителә. Анда ҮК әгъзалары (М.Вахитов, Х.Гайнуллин, М.Дулат-Али, Б.Мансуров, И.Рәхмәтуллин, Г.Садриев) һәм ҮК әгъзалыгына кандидатлар (Г.Исмәгыйлев, А.Касппранский-Измайлов, Х.Мәүлетов, Н.Яруллин) сайлана. РМКП программасына нигез итеп РКП(б)-ның 7 нче съездында В.И.Ленин тәкъдим иткән РКП(б) Программасы проекты алына. «Эшче» г-тасын нәшер итә. Партия 1918 нең ноябрендә *Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының беренче Бөтенроссия съезды* карары б-н таратыла, РМКП ҮК *РКП(б)ның мөселман оешмалары Үзәк Бюросы* итеп үзгәртелә.

*Әд.:* Мухарямов М.К. Октябрь и национальный вопрос в Татарии. К., 1958.

*Р.Г.Хәйретдинов.*

**РОССИ́Я МӨСЕЛМАННАРЫНЫ́Ң ВАКЫТЛЫ́ МӘРКӘ́З БЮРОСЫ́**, Бөтенроссия мөселманнары корылтаен чакыру буенча оештыру ком-ты. 1917 елның мартында 4 нче Дәүләт Думасындагы Мөселманнар фракциясе һәм Мөселман Бюросы әгъзалары тарафыннан Петроградта оештырыла. Рәисе — Ә.Цаликов, секретаре — И.Леманов, әгъзалары — С.Алкин, У.Баданинский, М.Бигиев, И.Бикколов, Ә.Вәлиди, С.Җантурин, С.Енгалычев, М.Кинчакский, Н.Корбангалиев, Мәүлетбирдиев, С.Максудов, Ш.Мөхәммәдъяров, Я.Мухмюр, К.Хәсәнов, Г.Терегулов. Төп максатлары — Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтаена әзерлек эшләрен башкару һәм аны чакыру, корылтайның программ документларын эшләү. Бюро кабул иткән нигезләмә буенча корылтай эшендә сәяси партияләр, мәдәни-агарту һ.б. мөселман оешмалары тарафыннан сайланган затлар, мөселманнар фракциясе һәм бюро әгъзалары катнаша ала. Бюро барлык мөселманнарның берләшү зарурлыгы нигезләнгән «Барлык Россия мөселманнарына» чакыру б-н мөрәҗәгать итә, корылтай чакыру көнен һәм урынын билгели — 1917 нең 1 мае, Мәскәү шәһәре. Вакытлы мәркәз бюросы 1917 нең маена кадәр гамәлдә була. «Известия Временного Центрального Бюро Российских Мусульман» («Россия мөселманнарының Вакытлы мәркәз бюросы хәбәрләре») г-тасын нәшер итә.

*Әд.:* Давлетшин Т. Советский Татарстан. Лондон, 1974; Тагиров И.Р. Революционная борьба и национально-освободительное движение в Поволжье и на Урале. К., 1977.

*Р.Г.Хәйретдинов.*

**РОССИ́Я СӘНГА́ТЬ АКАДЕ́МИЯСЕНЕҢ ИҖА́Т ОСТАХАНӘСЕ́** (1992 елга кадәр СССР СА), Казандагы аспирантура статусы булган уку йорты. 1977 дә Х.Г.*Якупов* башлангычы б-н СА президиумы карары нигезендә оештырыла. Идел буе төбәгендә яшәп иҗат итүче яшь рәссамнарның һөнәри күнекмәләрен камилләштерү максатында төзелә. Югары сәнгать уку йортларын тәмамлаучылар кабул ителә, кандидатлар СА президиумы тарафыннан раслана. Уку вакыты — 3 ел, соңыннан аспирантлар 2 программ нәкышь эше тәкъдим итәләр (остаханәнең картиналар фондына тапшырыла). Р.С.а.и.о.н Татарстан, Чуаш, Удмурт, Мари, Мордва һәм Россиянең башка респ-калары һәм өлкәләреннән 40 тан артык рәссам тәмамлый. Беренче чыгарылыш 1981 дә була. Алар арасында — В.Я.Акимов, З.Ф.Гыймаев, Ш.А.Нигъмәтуллин, С.П.Слесарский, В.А.Федотов, Ф.Г.Халиков, Ш.М.Шәйдуллин һ.б. Р.С.а.и.о. Россия САнең Идел буендагы остаханәләренең стажёрлары һәм җитәкчеләре әсәрләре күргәзмәсендә катнаша (Мәскәү, 2009). 1984 тә Казанда остаханә тәмамлаучыларның хезмәтләреннән күргәзмә оештырыла.

Остаханәнең җитәкчеләре: Х.Г.Якупов (1977–2008), А.Ә.Абызгилдин (2008 дән); референтлар: Г.Г.Ветлугин (1977–95), Ф.Х.Якупов (1995 тән).

*Әд.:* Якупов Ф.Х. Мастерская живописи // Казань. 2006. № 8/9.

*Г.Р.Фәйзрахманова.*

**РОССИ́Я СОВЕ́Т ФЕДЕРАТИ́В СОЦИАЛИ́СТИК РЕСПУ́БЛИКАСЫ** (РСФСР), к. *Россия Федерациясе.*

**РОССИ́Я ФӘННӘ́Р АКАДЕ́МИЯСЕНЕҢ КАЗА́Н ГЫЙЛЬМИ́ ҮЗӘГЕ́** (РФА КГҮ), акад. институтлар комплексы. Казанда СССР ФАнең бүлеген ачуга әзерлек, 1944 елда эвакуацияләнгән институтлар һәм комиссияләрне берләштереп, СССР ФАнең Казан учреждениеләр төркемнәре булдырылганнан соң башлана. 1945 тә СССР ФАнең Казан ф-лы оештырыла (СССР ФА КФ), аңа яңа оештырылган Химия, Физика-техника ин-тлары, Геол. ин-ты (хәзер Үзәк руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе ин-ты), Татар тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү ин-ты (элек ТАССР ХКС карамагында) керә. 1946 да Биол. ин-ты, 1958 дә Органик химия ин-ты ачыла. 1963 тә ФАнең КФ таркатыла; Биол. ин-ты Казан ун-тына, Геол. ин-ты СССР Геол. министрлыгына күчерелә; калган ин-тлар СССР ФА карамагында кала. 1973 тә СССР ФА КФ яңадан оештырыла, аның составына, Геол. ин-ты һәм берләштерелгән Органик һәм физик химия ин-тыннан тыш, барлык институтлар да кире кайтарыла. СССР ФА КФ 1990 да СССР ФАнең Казан гыйльми үзәге (КГҮ) итеп үзгәртелә, 1992 дән хәзерге исемдә. 1993 тә Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты ТР ФАнә күчерелә.



РФАнең Казан гыйльми үзәге бинасы. Хәзерге күренеше.

КГҮ федераль дәрәҗәдәге дәүләт фәнни-техник программасына керүче фундаменталь һәм практик (төп һәм гамәли) тикшеренүләрне координацияли. ТР ФА б-н бергәләп, эре респ-ка программалары һәм проектлары буенча алып барылган эшләрне координацияли. 1999–2003 тә КГҮ ТР ФА, югары уку йортлары һәм пр-тиеләр б-н хезмәттәшлектә хәзерге фәннең актуаль мәсьәләләренә багышланган 20 дән артык конференция уздыра. Югары белем һәм фундаменталь фәннәрне интеграцияләүгә дәүләт ярдәменең федераль максатчан программасы кысаларында Казан фәнни мәктәпләренең өстенлекле юнәлешләре буенча проектлар гамәлгә ашырыла, ел саен югары уку йортлары һәм ТР ФА б-н берлектә яшьләр фәнни мәктәпләре оештырыла.

Эшчәнлек б-н гомуми җитәкчелекне КГҮ президенты алып бара. КГҮ составында — *Органик һәм физик химия институты*, *Казан физика-техника институты*, *Казан Биохимия һәм биофизика институты*, *Механика һәм машина төзелеше институты*, Энергетика проблемаларын тикшерү үзәге — РФА КГҮ ф-лы. КГҮ Президиумы карамагында: мәгълүмат технологияләре бүлеге, мәгълүматны югары тизлектә эшкәртү үзәге, күмәк кулланудагы мәгълүмат үзәге, Үзәк фәнни китапханә (к. *Россия Фәннәр академиясе Казан гыйльми үзәгенең фәнни китапханәсе*). КГҮ ин-тлары һәм Казан югары уку йортлары б-н берлектә булдырылган 6 фәнни-укыту һәм фәнни-белем бирү үзәге эшли.

КГҮ элементорганик кушылмалар химиясе; электрон парамагнит һәм төш квадруполь резонанслары, молекуляр фотохимия, сыгулярнең нәсызыкча теориясе, аэрогидротыгызлык, җылылык энергетикасы һәм двигательләр төзелеше; үсемлекләр физиологиясе һәм биохимиясе, биофизика фәнни мәктәпләре б-н билгеле.

КГҮ галимнәре башкарган фундаменталь эшләр: полярлашкан кайтаваз һәм тәртипкә салынган ярымүткәргечләрне лазер нурында кристаллаштыру күренешләре ачыла; $^{37}Fe$ төшенең магнит моменты билгеләнә; рекордлы магнит анизотропиясенә ия булган сыек парамагнетик кристаллар синтезлана; фотосинтезның реакция үзәгендәге бүленгән корылмалы халәтләрнең электрон парамагнетик резонансы сызыкларының яктылык кайтавазы һәм квант тибеше күренеше теоретик фаразлана; бериш һәм бериш булмаган тирәлекләрнең һәм гидроаэросыгылмалы системаларның тирбәнешләре тикшерелә; нефтьле һәм суйөрткеч катламнарның фильтрлау параметрларын билгеләү алымнары эшләнә, үзле нефть һәм битумнарны чыгаруның термик алымнары фәнни нигезләнә, алар өчен техник чаралар эшләнә.

Фосфорорганик кушылмалар өлкәсендәге хезмәтләр медицина, вет., а.х., химия һәм нефть химиясе сәнәгатендә кулланыла торган препаратлар алу мөмкинлекләре ача. Элементорганик кушылмаларның төзелешен һәм реакциягә керү сәләтен ачыклау буенча фундаменталь тикшеренүләр гамәлгә ашырыла. Үсемлекләрдә сигнал системаларының уңайсыз экол.-климатик факторларга һәм патоген микроорганизмнарга чыдамлык формалаштыра торган яңа липид һәм олигосахаридлы катнашучылары табыла.

2014 тә КГҮ ин-тлары һәм бүлекләрендә 900 кеше эшли, ш.и. 523 фәнни хезмәткәр, шуларның 99ы — фән. д-ры, 327се — фән. канд.; РФА академиклары А.И.Коновалов, К.М.Салихов, О.Г.Синяшин, И.А.Тарчевский; РФА мөхбир әгъзалары И.С.Антипин, А.Н.Гречкин, Д.Ә.Гобәйдуллин, М.Ә.Илһамов, Е.Е.Никольский; 16 ТР ФА мөхбир әгъзасы, 21 фән д-ры һәм 290 фән канд.

СССР ФА КФ һәм КГҮ Президиумы рәисләре — А.Е.Арбузов (1945–63), М.М.Зарипов (1973–82), П.А.Кирпичников (1982–87), В.Е.Алемасов (1987–91), И.А.Тарчевский (1992–96), А.И.Коновалов (1996–2008), О.Г.Синяшин (2008).

**РОССИ́Я ФӘННӘ́Р АКАДЕ́МИЯСЕ КАЗА́Н ГЫЙЛЬМИ́ ҮЗӘГЕНЕ́Ң ФӘННИ́ КИТАПХАНӘСЕ́.** 1945 елда СССР ФАнең Казан ф-лы төзелү б-н бер вакытта оештырыла. Хәзер РФА КГҮ китапханәсе 3 структур бүлекчәдән — Үзәк Фәнни китапханә, *Органик һәм физик химия институты,* РФА КГҮнең Казан физика-техника институты китапханәләреннән тора. Китапханә акад. ин-тлар галимнәренә хезмәт күрсәтү өчен оеша, барлык белем бирү өлкәләре буенча комплектлаштырыла. Китапханә фонды структурасы табигыят һәм гуманитар фәннәр буенча фәнни хезмәтләрне, матур әдәбият, ш.у. махсус фондлар: тематик коллекцияләр, документлар җыелмасы, сирәк кульязма һәм китапларны үз эченә ала. Кыйммәтле тупланмаларга СССР ФАнең Азия халыклары ин-ты бүлекләре, А.И.Солженицын, Б.Н.Ельцин фондлары, галимнәрнең (А.М.Вилькен, М.Х.Корбангалиев һ.б.) шәхси китапханәләре керә. 17 йөздән 20 йөз башына кадәр сирәк китаплар фондында якынча 20 мең китап була. РФА КГҮ китапханәләренең гомуми фондында 500 мең берәмлектән артык китап исәпләнә, аларның якынча 170 меңе — чит телләрдә.



РФА КГҮнең фәнни китапханәсе.

РФА КГҮ китапханәсе хезмәткәрләре төбәкне өйрәнү, китап белеме, библиометрия, китапханә гыйлеме өлкәләрендә тикшеренүләр алып бара.

*Әд.:* М о р о з к и н а С.М. Эволюция библиотеки как интеллектуально-духовного топоса Казанского научного центра Российской академии наук // Вестн. Казан. гос. ун-та культуры и искусств: Спец. вып. К., 2007; Л у ч к и н а С.А. Библиотека по естественным наукам РАН. Итоги и перспективы. Сб. статей. М., 2008.

*С.А.Лучкина.*

**РОССИ́Я ФЕДЕРА́ЦИЯСЕ** (РФ, Россия), Европаның көнчыгыш өлешендә, Азиянең төньяк өлешендә урнашкан күпмилләтле дәүләт. Норвегия, Финляндия, Эстония, Латвия, Литва, Польша, Белоруссия, Украина, Грузия, Әзәрбайҗан, Казакъстан, Монголия, Кытай, Төньяк Корея, Япония, АКШ б-н чиктәш. Мәйданы 17125,2 мең *км²*. Халкы — 142,9 млн. кеше (2010), ш.и. руслар — 80,9%, татарлар — 3,87%, украиннар — 1,41%, башкортлар — 1,15%, чуашлар — 1,05%. 2010 елда РФдә 1100 шәһәр, 1286 штп, 153124 авыл торак пункты исәпләнә. Башкаласы — Мәскәү. Эре шәһәрләре: С.-Петербург, Новосибирск, Түбән Новгород, Екатеринбург, Самара, Омск, Казан, Уфа, Чиләбе, Ростов-Дон, Пермь, Волгоград. РФ субъектларын 22 респ-ка, ш.и. *Татарстан Республикасы*, ш.у. крайлар, өлкәләр, федераль әһәмияткә ия шәһәрләр (Мәскәү, С.-Петербург, Севастополь), автономияле өлкә һәм автономияле округлар тәшкил итә. Дәүләт башлыгы — РФ Президенты, ул ш.у. РФ Кораллы көчләренең Югары Башкомандующие вазифасын да башкара. РФнең вәкаләтле һәм законнар чыгаручы органы — Федераль җыен (парламент) — ике палатадан: Федерация Советы һәм Дәүләт Думасыннан тора. Башкарма хакимиятне рәис җитәкчелегендәге РФ хөкүмәте тормышка ашыра. Дәүләт гербы — канатлары киерелеп ачылган ике башлы алтын бөркет сурәте төшерелгән, түбәнге өлешендә почмаклары түгәрәкләнгән, уртасы очлаеп тәмамланган кызыл төстәге дүртпочмаклы геральдик калкан; бөркеткә кечерәк ике таҗ кидерелгән, аларны өченче — югарыдагы зур таҗ б-н уртак тасма тоташтыра; бөркетнең күкрәгендәге кызыл калканда — ат тоягы астында калган аждаһага көмеш сөңге кадап торган, көмеш атка атланган, зәңгәр япмалы көмеш җайдак сурәте. Дәүләт флагы — ак, зәңгәр һәм кызыл төстәге горизонталь буйлар төшерелгән полотно; гимн «Россия — священная наша держава» сүзләре б-н башлана.

РФ *Россия империясе* терр-ясендә барлыкка килә. 1917 елгы Окт. рев-циясе нәтиҗәсендә Петроградта Вакытлы хөкүмәт бәреп төшерелә, Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Советы хакимияте игълан ителә, башында В.И.*Ленин* торган яңа хөкүмәт — Халык комиссарлары советы (ХКС) төзелә. Җитәкчелеккә большевиклар килгәннән соң, Россиянең үзәк р-ннарында, Идел буенда (ш.и. Казанда; к. *Казанда 1917 елгы Октябрь кораллы баш күтәрелеше*), Уралда, Себердә, Ерак



Россия Федерациясенең Дәүләт гербы.

Көнчыгышта совет хакимиятен урнаштыру башлана. Совет хакимияте Россия халыкларының тигезлеген, аларның үзбилгеләнү хокукын игълан итә. Мөселманнарның дине, гореф-гадәтләре, милли һәм мәдәни оешмалары бәйсез дип белдерелә (к. «*Барлык Россия һәм Шәрекъ мөселман хезмәт ияләренә*»). Элекке Россия империясе терр-ясендә барган милли-дәүләт төзелешендәге үзгәрешләр барышында Украина Респ-касы оештырыла, Финляндиянең бәйсезлеге таныла. 1918 нең гыйнварында Россия Совет Федератив Социалистик Респ-касы (РСФСР) төзелә. Идел буе, Урал, Себердәге милли-демократик көчләр *милли-мәдәни мохтарият* идеясен тормышка ашыралар. *Идел-Урал Штаты* формасында татар һәм башкорт дәүләтчелеген булдыру эше башлана, тик большевикларның каршылыгына очрый (к. «*Болак арты республикасы*»). 1918 нең мартында үзәк хакимият тарафыннан, әлеге проектка җавап йөзеннән, ш.у. үтәлешенә ирешелмәгән *Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасы* төзү турында карар кабул ителә. Соңрак РСФСРның милли-дәүләт төзелеше Башкортстан АССР, Татарстан АССР, Кыргызстан АССР, Чуаш, Вотяк, Мари автономияле өлкәләре барлыкка килү һ.б. автономияле бүленешләр аша хәл ителә. Губерна, өяз, волостьлар урынына өлкә, край, кантон, районнар оештырыла. РСФСРда ТАССРның сәяси, икътисади, мәдәни мәнфәгатьләре *Татарстан Республикасының РСФСРдагы вәкаләтле вәкиллеге* арадашлыгында кайгыртыла. 1931 гә РСФСРда 14 край һәм өлкә, 11 автономияле респ-ка, 14 автономияле өлкә исәпләнә. РСФСР, 1922 дә Белоруссия ССР, Украина ССР, Кавказ арты ССР б-н бергә кушылып, *Совет Социалистик Республикалар Союзын* (СССР) хасил итә.

Үзгәртеп кору чорында (1980 еллар уртасыннан) союздаш респ-каларда «үзәктән качу» тенденцияләре көчәя башлый. 1990 ның июнендә РСФСР Халык депутатлары съезды РСФСРның дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул итә. 1991 нең мартында РСФСР президенты посты булдырылып, ул вазифага Б.Н.*Ельцин* сайлана. РСФСРның кайбер автономияле респ-каларында, аерым алганда ТАССРда, автономияләрнең статусын күтәрүгә юнәлтелгән хәрәкәт көч ала; 1990 ның августында *Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт суве-*



Россия Федерациясенең Дәүләт флагы.

*ренитеты турында Декларация* кабул ителә. 1991 нең август–сентябрендә союздаш респ-каларның күпчелеге бәйсезлекләре турында белдерү б-н чыгалар. 1991 нең декабрендә РСФСР, Белоруссия ССР, Украина ССР җитәкчеләре тарафыннан СССРның таркалуы һәм *Бәйсез Дәүләтләр Берләлеге* төзелү рәсми рәвештә расланган Беловежье килешүенә кул куела. Россия, СССРның хокукый варисы буларак, БМОның Куркынычсызлык Советында урын ала, элекке союз дәүләтенең халыкара-хокукый килешүләр б-н билгеләнгән бурычларын үтәүне үз өстенә алуын таный.

1990 елларда РФнең сәяси, социаль-икътисади тормышындагы төп вакыйгалар икътисади реформалар, 1993 елгы сәяси кризис, Чечен Респ-касындагы сугыш б-н бәйле була. Федератив мөнәсәбәтләр үсеше 1992 дә кабул ителгән, үзәкнең респ-калар, крайлар, өлкәләр, автономияле округлар б-н үзара мөнәсәбәтләрен билгеләгән Федератив шартнамәдә чагылыш таба. 1994 тә «*Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында шартнамә*»гә кул куела. Шартнамә нигезендә хәрби төзелеш, хәрби-сәнәгать комплексы, бюджет, таможня, финанслар, тышкы икътисади эшчәнлек һ.б.га кагылышлы килешүләр төзелә. РФ һәм ТРның дәүләт хакимияте органнары тарафыннан Мәскәү һәм Казанда вәкаләтле вәкиллекләр булдырыла (к. *Татарстан Республикасының вәкиллекләре*). РФ терр-ясенең татарлар тупланып яшәгән төбәкләрендә *татарларның милли-мәдәни автономиясе* төзелә. 2007 елгы «*Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында шартнамә*»дә ТРның РФ субъекты булуы, РФдән һәм РФ вәкаләтләреннән читтәге РФ һәм аның субъектларына кагылышлы уртак эшләрдә тулы дәүләт хакимиятенә ия икәнлеге әйтелә. ТР хәзерге чорда РФнең сәяси һәм икътисади яктан иң тотрыклы төбәкләреннән санала. 2000–14 елларда, В.В.*Путин* (2000–08, 2012 дән) һәм Д.А.*Медведев* (2008–12) РФ Президенты булган чорда, сәламәтлек саклау, мәгариф, фән, а.х. һәм торак хуҗалыгы, хәрби төзелеш, хокук саклау системасы өлкәсендә реформалар уздырыла.

*Әд.:* Новая Российская энциклопедия. М., 2003.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**РОССИ́Я ФЕДЕРА́ЦИЯСЕ ГЕРОЕ́**, 1992 елдан РФдә бирелә торган югары дәрәҗәле мактаулы исем, олы хөрмәткә лаек булу билгесе. Дәүләт һәм халык мәнфәгатен яклап аеруча зур каһарманлык, батырлык күрсәтүчеләргә РФ Президенты карары б-н бирелә. Геройларга югары дәрәҗәдә танылу билгесе — «Алтын Йолдыз» медале һәм Р.Ф.Г. исеме бирелү турында грамота тапшырыла; аларга закон буенча каралган ташламалар бирелә. «Алтын Йолдыз» медале сул якка, орденнар һәм медальләрдән өскәрәк тагыла. ТРда бу исемгә лаек булучылар — 11 кеше: А.Н.Епанешников, В.Ф.Ерин, О.Н.Исаев, Г.Г.Хәйруллин, В.И.Шарпатов, А.В.Козин, А.М.Кораблёв, Л.С.Попов, И.Д.Сафин, Г.С.Смирнов, А.А.Супонинский. Чыгышлары б-н РФнең башка респ-ка, край һәм өлкәләреннән булган татарлар — Россия Федерациясе Геройлары 29 кеше (В.Р.Алимов, Р.Ә.Бариев, В.В.Нургалиев, Т.Г.Сиражетдинов, И.К.Уразаев, Ф.А.Якупов, Ж.Ж.Яфаров һ.б.).



Россия Федерациясе Героеның «Алтын Йолдыз» медале.

**«РОССИ́Я ФЕДЕРА́ЦИЯСЕ ДӘҮЛӘ́Т ХАКИМИЯТЕ́ О́РГАННАРЫ ҺӘМ ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ДӘҮЛӘ́Т ХАКИМИЯТЕ́ О́РГАННАРЫ АРАСЫНДА́ ЭШЛӘ́Р ҺӘМ ВӘКАЛӘТЛӘ́Р БҮЛЕШҮ́ ТУРЫНДА́ ШАРТНАМӘ́»**, РФ һәм ТР дәүләт хакимияте органнары арасындагы шартнамә. «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» дип аталган беренче Шартнамә 1994 елның 15 февралендә РФ Президенты Б.Н.Ельцин, РФ Хөкүмәте Рәисе В.С.Черномырдин, ТР Президенты М.Ш.Шәймиев һәм ТР Премьер-министры М.Г.Сабиров тарафыннан имзалана. Шартнамә кереш өлештән һәм 9 маддәдән тора. Анда Шартнамәне төзегәндә якларның халыкларның гомумтанылган үзбилгеләнү хокукыннан, тигез хокуклылык, үзирекләлек, ихтыяр белдерү ирекле принципларыннан чыгып эш итүләре күрсәтелә, яклар терр. бөтенлекне һәм икътисади пространство бердәмлеген саклауны гарантияләү, тарихи һәм милли традицияләрне, мәдәниятләрне һәм телләрне саклауга һәм үстерүгә ярдәм итү, гражданнарның тынычлыгын, милләтара татулыкны һәм халыклар иминлеген тәэмин итү, нинди милләттән булуга, нинди дин тотуга, яшәү урынына һәм башка үзенчәлекләргә бәйсез рәвештә кешенең һәм гражданның төп хокуклары һәм ирекләре өстенлеген гамәлгә ашыру йөкләмәләрен алалар. ТР дәүләт хакимияте органнарының төп вәкаләтләренә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау; респ-ка гражданлыгы мәсьәләләре; респ-ка бюджетын төзү, респ-ка салымнарын раслау һәм җыю; Татарстан терр-ясендә дәүләт милкенә ия булу, куллану һәм идарә итү; респ-ка дәүләт органнары системасын, аларны оештыру һәм эшләү тәртибен булдыру; халыкара мөнәсәбәтләрдә катнашу һ.б. керә. Шартнамәдә берлектә гамәлгә ашырыла торган вәкаләтләр һәм РФ карамагына тапшырылган мәсьәләләр исемлеге бирелә. Ахыргы маддәләрдә РФ һәм ТР дәүләт хакимияте органнарының үз карамакларында булмаган мәсьәләләр буенча хокукый актлар булдыра алмаулары ассызыклана. Шартнамәне бозучы законнар үз көченнән чыгарыла ала, бәхәсләр яклар килешүе тәртибендә хәл ителә. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен якларның өстәмә килешүләр төзүе, уртак структуралар оештыруы карала. РФ һәм ТР дәүләт хакимияте органнары Мәскәүдә һәм Казанда вәкаләтле вәкиллекләр булдыралар. Әлеге Шартнамә нигезендә хәрби төзелеш, хәрби сәнәгать комплексы, бюджет, таможня, финанс, тышкы икътисади эшчәнлек һ.б. турында хөкүмәтара килешүләр имзалана.

«Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр...» дип аталган яңа Шартнамә 2007 нең 26 июнендә РФ Президенты В.В.Путин, ТР Президенты М.Ш.Шәймиев тарафыннан имзалана һәм 2007 нең 24 июлендә РФнең Федераль законы сыйфатында раслана. Шартнамә кереш өлештән һәм 6 маддәдән тора. Анда Шартнамәне төзегәндә якларның Татарстанның тарихи, мәдәни һәм башка үзенчәлекләреннән чыгып эш итүләре, РФ Конституциясенә һәм ТР Конституциясенә туры китереп, Татарстан Республикасының 1992 нең 15 февралендә уздырылган референдумы нигезендә 1994 нең 15 февралендә төзелгән Шартнамәне куллану тәҗрибәсен исәпкә алулары күрсәтелә. Шартнамәдә Татарстан Республикасының Россия Федерациясе субъекты булып торуы, РФ карамагындагы эшләр һәм РФнең РФ һәм аның субъектларының уртак карамагындагы эшләр буенча вәкаләтләреннән тыш дәүләт хакимиятенең барлык тулылыгына ия булуы билгеләп үтелә. Татарстан терр-ясендә җир, җир асты байлыклары, су, урман һ.б. табигый ресурслардан файдалану һәм аларны саклау аның күпмилләтле халкының тормышы һәм эшчәнлеге нигезен тәшкил итүен исәпкә алып, яклар респ-каның икътисади, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләре б-н бәйле мәсьәләләрне берлектә хәл итү турында килешенәләр. Үзләренә кагылышлы проблемалар буенча РФ Хөкүмәте һәм ТР Дәүләт Советы тиешле закон проектларын РФ Федераль Җыенының Дәүләт Думасы каравына кертәләр. Үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан чит илләрнең субъектлары һәм адм.-терр. берәмлекләре б-н халыкара һәм тышкы икътисади багланышларны гамәлгә ашыра, халыкара оешмалар органнары эшчәнлегендә катнаша, ш.у. халыкара һәм тышкы икътисади багланышларны тормышка ашыру турында килешүләр төзи, башка илләрнең дәүләт хаки-

мияте органнары б-н шундый багланышларны гамәлгә ашыра (РФ Тышкы эшләр министрлыгы б-н килештереп); ТРдан читтә яшәүче татарларга үзенчәлекләрен саклауда, милли мәдәниятне һәм телне үстерүдә дәүләт ярдәмен һәм булышлыгын күрсәтә (РФ Хөкүмәте б-н килештереп). Шартнамәдә рус һәм татар телләренең ТРның дәүләт телләре булуы, ТРның иң югары вазифаи заты булуны дәгъвалаган кандидатлар өчен ТРның ике дәүләт телен белүе турындагы өстәмә таләп билгеләнүе раслана. Татарстан терр-ясендә яшәүче РФ гражданнары РФ гражданының татар телендәге өстәмә битендә ТРның дәүләт гербы сурәте урнаштырылган гомумгражданлык паспортын алырга хокуклы. Яклар ТР дәүләт хакимияте органнарының РФ Президенты каршында Мәскәүдә тиешле вәкиллеге булуы турында килешенәләр. Шартнамәнең гамәли срогы — 10 ел. Аның гамәлен озайту, срогыннан алда туктату (Шартнамәне өзү) тәртибе һәм нигезләре федераль закон б-н билгеләнә.

*Әд.:* Железнов Б.Л. Правовой статус Республики Татарстан. К., 1996; Договор Российской Федерации и Республики Татарстан: Пять лет развития. К., 1999; Тагиров И.Р. История государственности Татарстана. XX век. К., 2005.

*Р.А.Сәхиева, Е.Б.Долгов.*

**РОССИ́Я ФЕДЕРА́ЦИЯСЕ КОММУНИСТЛА́Р ПА́РТИЯСЕНЕҢ ТАТАРСТА́Н РЕГИОНА́ЛЬ БҮЛЕГЕ́** (РФКП ТРБ), сәяси партия бүлекчәсе. 1991 елның декабрендә, 1 нче оештыру конференциясендә элеккеге КПСС әгъзалары А.И.Архипов, В.Д.Машков, Л.Х.Усманова, С.Н.Шулаева, Ф.Г.Галиханов, Н.А.Каюков, Р.Г.Сабитов, В.А.Саламашкин, А.Ш.Фәхретдинов, И.Б.Фәттахов һ.б.ны берләштергән төркем тәкъдиме б-н ТР Коммунистлар оешмасы (ТРКО) буларак гамәлгә куела. Конференциядә РСФСР Коммунистлар партиясен тыю турында Россия Президенты Б.Н.Ельцин Указының Конституциягә каршы килүе хакында белдерү ясала; ТРКОның КПССның Татарстан респ-ка оешмасы дәвамчысы булуы турында игълан ителә; оешманың Уставы һәм Программ документлары раслана. 1993 нең ноябрендә ТРКО Татарстан Респ-касы Коммунистлар партиясе (ТРКП) дип үзгәртелә, 1997 нең февралендә, автономияле оешма буларак, РФКП составына кертелә; 2002 нең гыйнварыннан хәзерге исемдә. 2002 гә кадәр оешманың структурасы ТРКО-ТРКП Уставы нигезендә төзелә. 1991–1993 елларда партиянең иң югары органын конференция тәшкил итә. Барлыгы 3 конференция уздырыла: 1 нчесе ике этапта үтә: 1991 нең 14–15 декабре һәм 1992 нең 17 июне (Казан), 2 нчесе — 1993 нең 6 марты (Казан), 3 нчесе — 1993 нең 20 ноябре (Чаллы). 1993–2002 елларда иң югары орган булып съезд тора. Барлыгы 10 съезд (барысы да Казанда) уздырыла: 1 нчесе — 1994 нең 24–25 июне, 2 нчесе — 1996 ның 6 гыйнвары, 3 нчесе — 1997 нең 15–16 феврале, 4 нчесе — 1997 нең 5 ноябре, 5 нчесе — 1998 нең 25 феврале, 6 нчысы — 1999 ның 6 феврале; 7 нчесе ике этапта үтә — 1999 ның 29 августы һәм 1999 ның 16 октябре; 8 нчесе — 2000 нең 23–24 сентябре; 9 нчысы ике этапта үтә — 2000 нең 21–22 октябре һәм 2000 нең 24 декабре; 10 нчысы ике этапта үтә — 2002 нең 5 гыйнвары һәм 2002 нең 26 гыйнвары. 10 нчы съездның икенче этабы барышында ТРКПның 10 нчы съезды РФКП ТРБнең 10 нчы конференциясе дип үзгәртелә. Шушы вакыттан иң югары орган булып конференция санала, съездларның дәвамчысы буларак, конференцияләрнең тәртип саны ТРКП съездларының тәртип саныннан исәпләнә: 11 нче конференция өч этапта — 2003 нең 1–2 мартында, 2003 нең 3 августында һәм 2003 нең 30 декабрендә (Казан), 12 нчесе — 2004 нең 13 июнендә (Казан), 13 нчесе 2005 нең 13 августында (Чаллы) уздырыла. Конференция-съезд — партиянең респ-ка ком-тын (реском) һәм контроль-ревизия комиссиясен, реском пленумы аның бюросын һәм секретариатын сайлый. Рескомның 1 нче секретарьлары — А.И.Салий (1992–2004), Х.Г.Миргалимов (2004 тән); идеология буенча секретарьлары — Р.Г.Садыйков (1992–2004), В.И.Кострин (2004 тән); кадрлар буенча секретаре — В.Д.Машков (1992–97, шуннан соң бу вазифа бетерелә); оештыру-партия эше буенча төрле еллардагы секретарьлар — Н.А.Каюков, И.М.Ларюхин, И.М.Шакулов, А.Г.Федин, 2004 тән — М.С.Сәмигуллин; а.х. буенча секретарь — М.А.Солтанов, сәнәгать буенча секретарь — Н.Н.Максимов (2004 тән). Җирле оешмалар респ-каның адм.-терр. берәмлекләре кысаларында эшчәнлек алып бара. Аларның иң югары һәм җитәкче органы булган конференция (гомуми җыелыш) район (шәһәр) ком-тын һәм контроль-ревизия комиссиясен сайлый. Район (шәһәр) ком-тлары секретарь (кечерәк оешмаларда) яки башында 1 нче секретарь торган бернечә секретарь (зуррак оешмаларда) сайлап куя. Җирле оешмалар саны: 1992 дә — 32, 1993 тә — 42, 1995 тә — 50, 1997 дә — 47, 2004 тә — 33. Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Яшел Үзән шәһәрләрендәге оешмалар иң күпсанлылардан санала һәм актив сәяси эшчәнлек алып бара. Партия әгъзаларының саны турында төгәл мәгълүмат юк: 332 кеше (1992, февраль), 552 (1992, июль), 5 мең (1992, декабрь), 8,2 мең (1993, апрель), 17 мең (1994, июнь), 20 мең (1995, октябрь), 15 мең (2000, октябрь), 4,4 мең (2003, декабрь), 3,8 мең (2004, июль), 1,5 мең (2004, ноябрь). Партия сафларында торучыларның күпчелеген өлкән яшьтәгеләр тәшкил итә. 1990 елларда җитәкчелек тарафыннан партиянең яшьләр оешмасын булдыру омтылышлары ясала: 1998 дә ТРның Ленинчыл Коммунистик Яшьләр Берлеге (ТР ЛКСМы) гамәлгә куелып, ул тиз арада таркала, 1999 да Россия Федерациясе Коммунистик Яшьләр Берлегенең Татарстан региональ бүлеге (РФКЯБ ТРБ) оештырыла. Партиянең марксизм-ленинизм концепциясенә нигезләнгән һәм «программа-минимум», «программа-максимум» өлешләреннән торган программасы ТРКПнең 1 нче съездында (1994) кабул ителә һәм 2002 гә кадәр гамәлдә була. Төп максатлары — Совет хакимиятен кире кайтару; СССРны торгызу һәм Татарстанга союздаш респ-ка статусы алу; халык депутатларын сайлауда күппартиялелек нигезендәге җитештерү-терр. принципка күчү; массакүләм мәгълүмат чаралары эшчәнлеген Советлар күзәтчелегенә кую; хосусыйлаштырылган милекне национализацияләү; бәяләр сәясәте, банклар эшчәнлеге һәм тышкы сәүдә өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге урнаштыру; хезмәт ияләренә тиешле социаль гарантияләрне тергезү; фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният һәм спорт өлкәләрен дәүләтнең киң колачлы ярдәме б-н тәэмин итү; җәмгыятьтә социаль гаделлек, гуманизм, коллективизм, патриотизм һәм халыклар дуслыгы кыйммәтләрен яңадан торгызуга ирешү. ТРКПнең РФКП ТРБ дип үзгәртелүеннән соң, рәсми программ документ булып РФКП программасы санала. Кайбер мәсьәләләргә карашта ТРКП программасыннан сизелерлек аермалары булуга карамастан, ул, нигездә, марксизм-ленинизм концепциясенә таяна. Хезмәт һәм капитал арасындагы каршылыклар чыганагы булып калучы яңа чор капитализмына карата кискен тәнкыйть аның өчен этәргеч принцип булып тора. Хәзерге вакытта әлеге конфликт бер дәүләт эчендәге аерым социаль төркемнәр каршылыгында гына түгел, ш.у. глобаль дәрәҗәдә — сәнәгать ягыннан үскән Төньяк (кешелекнең «алтын миллиарды») һәм үсеп килүче Көньяк арасындагы каршылыкта да чагылыш таба. Капитализмның күпмедер күләмдә үсеш потенциалына ия булуын таныган хәлдә, РФКП аның алга таба кешелек цивилизациясен җимерәчәк глобаль һәлакәткә, беренче чиратта экологик һәлакәткә китереп җиткерәчәге турында белдерә. Коммунистлар фикеренчә, моны булдырмас өчен, һәр ил «тотрыклы үсеш»кә юнәлдерелгән үз альтернатив программасын эшләргә тиеш. Россиянең социаль юнәлешне сайлавы нигезле дип күрсәтелә. РФКП идеологлары күзлегеннән социализм — иҗтимагый үсешнең, кулланудан бигрәк, рухи мәнфәгатьләр өстенлегенә корылган формасы; социаль-икътисади яктан караганда, иң мөһиме җитештерү һәм куллануның иҗтимагый рәвештә тормышка ашырылуы булачак. Россиянең тарихи үткәненә бәя биреп, РФКП идеологлары КПСС диктатурасы заманнарының кайбер күзаллауларыннан читләшергә омтылалар. Мәс., алар дини учреждениеләрнең ролен уңай бәяләр, Россиянең рев-циягә кадәрге бай мәдәни һәм рухи мирасын кире какмыйлар, Окт. рев-циясе нәтиҗәсендә барлыкка килгән Советлар Союзын Россия империясенең геосәяси варисы сыйфатында кабул итәләр. Шушы контекстта ватан кыйммәтләре һәм рус милли идеясе алар тарафыннан рәсми рәвештә таныла. Совет моделе кризисы сәбәпләренең берсен алар КПСС кысаларында ике агым — «пролетар (демократик)» һәм «вак буржуаз (бюрократик)» агымнар хөкем сөрүдә күрәләр, шушы ике агым арасында барган көрәш «партиягә һәм милли мәнфәгатьләргә хыянәт иткән» төркемнең җиңүе һәм СССР таркалу б-н тәмамланды, дип саныйлар. Шуннан соң башланган капиталистик мөнәсәбәтләрне тергезү, алар фикеренчә,

җәмгыятьнең барлык сәяси һәм социаль-икътисади инфраструктурасы җимерелеп төшүгә, халыкның хәерчеләнүенә һәм деградациясенә китерә. Сайлауларда җиңеп чыккан һәм хакимияткә килгән очракта, РФКП халык ышанычына нигезләнгән хөкүмәт төзергә; советлар системасын торгызырга; җитештерүне көйләү һәм халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү максатыннан, икътисади курсны үзгәртергә һәм дәүләт тарафыннан көйләү чаралары күрергә; стратегик товарлар б-н сәүдә итүдә дәүләт монополиясе кертергә; гражданнарның хезмәткә, ялга, бушлай белем алуга һәм мед. ярдәменә хокукын кире кайтарырга; җинаятьчелек, коррупция, спекуляция б-н көрәш чараларын аяусызландырырга; русофобия, көнбатышчылык һәм америкача яшәү рәвешен көчләп кертү күренешләрен туктатырга вәгъдә итә. Вакытлы матбугат басмалары — «Слово коммуниста» (1993–2003), «Казанская искра» (2003 тән), «Знамя коммунизма» (Чаллы), «Челнинская правда» (1997–98) г-талары.

Партиянең йогынтысы 1990 елларда, Татарстан сәяси оппозициясенең төп көчләреннән берсен тәшкил иткән чорда зур була. ТРКП төрле дәрәҗәдәге сайлау кампанияләрендә активлык күрсәтә. 1993 нең сентябрендә ТРКО 12 нче чакырылыш ТР ЮСна сайлауларда катнаша. 2 нче чакырылыш РФ Дәүләт Думасына (1995–99) А.И.Салий, М.Ф.Ганиев, Н.К.Столярова, 1 нче чакырылыш ТР Дәүләт Советына (1995–99) А.В.Александров, М.Х.Вафин, Н.И.Коробков, В.Б.Паймухин сайлана; коммунистлар җирле Советларда да була. Шушы ук чорда партия гомумроссия коммунистик хәрәкәте б-н элемтәләрен ныгыта. 1993 тә оешкан РФКП б-н ике арада фикер каршылыклары да туа. ТРКП идеология мәсьәләләрендә РФКПнә караганда ортодоксальрәк караш та тора. Бу Татарстан партиясе сафларында байтак санда төрле сул агым вәкилләре (ш.и. сталинизм яклылар) булу б-н аңлатыла, аларның күпчелеге ул чорда, «ревизионизм»да гаепләп, РФКП программасын кире кага. Шулай да Татарстан коммунистларының сайлауларда РФКП б-н бергәләп катнашуы ТРКПнең РФКП составына керүе мәсьәләсен көн кадагына куя. 1997 нең февралендә ТРКПнең 3 нче съездында мәсьәлә уңай хәл ителә. В.Д.Машков һәм М.Г.Фёдоров җитәкчелегендәге бер төркем делегатлар әлеге карарга каршы чыга. Соңрак алар партиядән чыгалар һәм 1998 дә ТР Коммунистлар (большевиклар) партиясен оештыралар, яңа оешма берничә елдан таркала. 1990 еллар ахырында ТРКП җитәкчелеге респ-каның башка оппозицион көчләре вәкилләре б-н хезмәттәшлекне активлаштырырга омтылыш ясый: ТРдагы сәяси партияләр һәм иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләрнең 1994 тә оешкан «Түгәрәк өстәл» коалициясе эшчәнлеге яңартыла, ТРКП анда әйдәүче ролендә катнаша. Шуңа да карамастан, партия акрынлап респ-када үз йогынтысын югалта бара: 3 нче чакырылыш Дәүләт Думасына (1999–2003) бары А.И.Салий гына сайлана, 2 нче чакырылыш ТР Дәүләт Советы составына ТРКП әгъзалары керми кала. Р.Г.Садыйков 2001 дә ТР Президентын сайлауларда үз кандидатурасын тәкъдим итә, ләкин җиңүгә ирешми. 2001 нең сентябрендә ТРКП канаты астында Россия халык патриотик берлеге оеша. 2001 дә «Сәяси партияләр турында» Федераль закон кабул ителгәннән соң, төбәк сәяси берләшмәләре һәм партияләре эшчәнлеге тыела. Әлеге шартларда ТРКП үзенең автономияле статусыннан баш тартырга мәҗбүр була һәм РФКП ТРБ итеп үзгәртелә. 3 нче чакырылыш ТР Дәүләт Советына сайлауларда РФКП ТРБ үзенең дүрт вәкилен депутатлыкка уздыруга ирешә, һәм алар (А.И.Салий, Р.Г.Садыйков, Н.К.Столярова, Х.Г.Миргалимов) партиянең фракциясен төзиләр.

*Әд.:* Терентьева И.В., Беляков Р.Ю., Сафаров М.Ф. Политические партии и движения Республики Татарстан. К., 1999; шулар ук. Республика Татарстан: политические партии, движения, лидеры. К., 2003.

*М.Ф.Сәфәров.*

**РОССИ́Я ФЕДЕРА́ЦИЯСЕНЕҢ ИДЕ́Л БУЕ́ ФЕДЕРА́ЛЬ О́КРУГЫ**, РФнең җиде адм.-терр. берәмлекләреннән берсе. РФ Президентының 2000 ел 13 май Указы нигезендә оештырыла. Мәйданы 1035,9 мең *км²* (Россия терр-ясенең 6,1% ы). Халкы — 32156,8 мең кеше (РФ халкының 21,8% ы). Татарстан, Башкортстан, Мари, Мордва, Удмурт, Чуаш Респ-каларын; Пермь краен, Киров, Түбән Новгород, Оренбург, Пенза, Самара, Саратов, Ульянов өлкәләрен берләштерә. Үзәге — Түбән Новгород шәһәре. Р.Ф.И.б.ф.о. Россиянең иң куәтле индустриаль һәм аграр төбәкләреннән санала. Округта автомобильләр һәм судноләр төзү, төгәл һәм катлаулы приборлар, станоклар эшләп чыгару, авиация, электр химиясе һәм инструментлар ясау сәнәгате, электрон машиналар төзелеше, нефть-газ химиясе комплексы өчен технологияләр җитештерү, тракторлар төзү, ягулык сәнәгате аеруча зур үсеш алган. Төбәк нефть һәм газ запаслары бай. РФ Президентының Р.Ф.И.б.ф.о.ндагы вәкаләтле вәкиленә федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү, округтагы федераль органнар эшчәнлеген координацияләү, хокук саклау органнары эшчәнлегенә анализ ясау, РФ дәүләт хакимияте органнары һәм РФ субъектлары дәүләт хакимияте органнары арасындагы фикер каршылыкларын хәл итү өчен килештерү чаралары күрү һ.б. функцияләр йөкләнә.

Вәкаләтле вәкилләр — С.В.Кириенко (2000–05), А.В.Коновалов (2005–08), Г.А.Рапота (2008–11), М.В.Бабич (2011 дән).

*Е.Б.Долгов.*

**РОССИ́Я ҺӘМ БДБНЫҢ ЕВРО́ПА ИЛЛӘРЕ́ МӨСЕЛМАННАРЫ́ ҮЗӘ́К ДИНИЯ́ НӘЗАРӘТЕ́**, Екатерина IIнең «Мөхәммәд канунындагы муллаларны һәм башка дини чиннарны билгеләү һәм Уфада Россиядә яшәгән барлык дини чиннар белән идарә итүче дини канун Җыены оештыру турында»гы Фәрманы нигезендә 1788 елның 22 сентябрендә Уфа Дини Мөхәммәди Канун Җыены оештырыла. 1789 ның 4 декабрендә Уфада ачыла, 1796–1802 дә Оренбургта урнаша. Исеме 1796 дан — Оренбург Дини Мөхәммәди Канун Җыены, 1846–1917 дә — Оренбург Дини Мөхәммәди җыены, 1917–48 дә — Эчке Россия һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте, 1948–92 дә СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәте дип йөртелә, 1994 тән — хәзерге исемендә. 1917 елга кадәр Эчке Россия һәм Себер мөселманнарын берләштерә; 1912 гә кадәр аның карамагында 32 губернада яшәүче 4,5 млн.нан артык мөселман, 5771 мәхәллә һәм 12,3 млн.нан күбрәк рухани була. Оренбург Дини Мөхәммәди Җыенында дини вазифалар бирү алдыннан руханилардан ислам кануннары буенча имтихан алына, аларның эшчәнлеге даими тикшереп-күзәтеп торыла, мәчетләр төзү һәм төзекләндерү, метрика кенәгәләрен алып бару, никах, мөлкәткә караган бәхәсләр, *вакыф*лар мәсьәләсе һ.б. эшләр карала. 1917 гә кадәр мөфти лояль руханилар арасыннан билгеләп куела, ш.у. муллалар, казыйлар һ.б. вазифаларына указлар бирү ин-тлары була. 1917 дән соң мөфти сайлау системасы кертелә. Совет дәүләтенең алга таба дингә каршы тоткан сәясәте Диния нәзарәтенең функцияләрен нык чикли. Үзәк Мөселман Диния нәзарәте (ҮМДН) 28 төбәк мөселман Диния нәзарәтен һәм 2,5 меңнән артык мөселман җәмгыятен (2002) берләштерә. ҮМДНнең зур дини үзәкләре Казан, Екатеринбург, Киев, Мәскәү, Минск, С.-Петербург һ.б. шәһәрләрдә урнашкан. Россия ҮМДНнең җитәкче органнары — Мәҗлес (съезд), Президиум, Мөфтиләр Шурасы, Голямалар Шурасы. Төп матбугат органы — «Мәгълүмат» («Известия») ж-лы. Төрле елларда эшләгән мөфтиләр — М.*Хөсәенов* (1788–1824), Г.*Габдрәхимов* (1825–40), Г.*Сөләйманов* (1840–62), С.Тәфкилев (1865–85), М.*Солтанов* (1885–1915), М.*Баязитов* (1915–17), Г.*Баруди* (1917–21), Р.*Фәхретдинов* (1923–36), Г.Рәсүлев (1936–50), Ш.Ш.Хәялетдинов (1951–74), Г.*Исаев* (1975–80), Т.Таҗетдин (1980 нән). Ш.у.к. *Татарстан Республикасы Мөселманнарының Диния нәзарәте*.

*Әд.:* Азаматов Д.Д. Оренбургское магометанское духовное собрание в конце XVIII–XIX вв. Уфа, 1999; Хабутдинов А.Ю. Российские муфтии: От екатерининских орлов до ядерной эпохи. Н.Новгород, 2006; Ислам на Урале: Энцикл. словарь. М.–Н.Новгород, 2009.

**РОССИ́ЯДӘ БЕРЕНЧЕ́ КҮЧМӘ́ МӨСЕЛМА́Н ДРА́МА АРТИСТЛАРЫ́ ТРУ́ППАСЫ**. 1905 елда Оренбург шәһәрендә И.*Кудашев-Ашказарский* тарафыннан оештырыла. А.Н.Островскийның «Наданлык илә галимлек» («В чужом пиру похмелье», сүзгә-сүз — «Учёные и невежды», афишада — «Яктылык илә караңгылык» — «Свет и тьма») пьесасына, ш.у. Н.В.Гогольнең «Ревизор», А.С.Грибоедовның «Акыллылык бәласе» («Горе от ума») пьесаларыннан өзекләргә нигезләнгән беренче спектакль 1905 нең 3 декабрендә күрсәтелергә тиеш була, әмма иске карашлы руханилар һәм сәүдәгәрләр басымы б-н шәһәр хакимиятләре тарафыннан тыела (афишасы сакланып калган). Халыкка татар телендә беренче спектакль 1907 нең 3 апрелендә күрсәтелә: И.Кудашев-Ашказарский труппасы Ф.Халидинең «Морат Сәлимов» драмасын һәм А.П.Чеховның «Тәкъ-

дим» («Предложение») водевилен тәкъдим итә. 1907 нең 19 маенда И.И.Гедике һәм А.Ф.Минаевның җәйге театрында икенче спектакль («Яктылык илә караңгылык» — «Свет и тьма» һәм З.Б.Осетровның «Төнге тревога» — «Ночная тревога» әсәрләре буенча) куела. Ул рус труппасы тарафыннан уйнала. Актёрлар арасында В.Мортазин-Иманский, Ә.Кулалаев (Ишморатов), Н.Гайнуллин, Н.Сакаев була, хатын-кыз рольләрен А.Вәлиев башкара. Оренбургта берничә тамаша күрсәткәннән соң, труппа Россия шәһәрләре — Самара, Сембер буйлап гастрольләргә чыга; 1907 нең 13 июлендә коллектив Казанда *«Аркадия» бакчасындагы* җәйге театрда чыгыш ясый. Шул ук елда Касыйм, Түбән Новгород (ярминкәдә) һәм Мәскәүдә спектакльләр (репертуарда — Х.Зәбиринең «Төшенү, яхуд Указ бәласе», Г.Исхакыйның «Өч хатын берлән тормыш», Н.В.Гогольнең «Өйләнү» («Женитьба») әсәрләре, А.П.Чеховның «Җинаятьче» («Злоумышленник») һәм «Хирургия» хикәяләренең инсценировкалары) күрсәтә. Түбән Новгородта труппа составына С.Гыйззәтуллина-Волжская, Ф.Шаһимәрдәнова, тиздән әйдәп баручы актёр булып киткән Г.Кариев керә. Нәтиҗәдә, коллективта театрның үсеш юлларына мөнәсәбәтле фикер каршылыклары килеп чыгу һәм Мәскәүдәге гастрольләренең уңышсыз булуы сәбәпле, труппа таркала. Актёрларның күпчелеге Г.Кариев б-н кала һәм киләчәктә булачак *«Сәйяр»* труппасының нигезен тәшкил итә. И.Кудашев-Ашказарский труппаның үз өлешен яңа актёрлар б-н тулыландыра һәм аның элекке исемен саклап кала. Репертуарны Г.Исхакый («Өч хатын берлән тормыш»), Г.Камал («Беренче театр», «Уйнаш», «Дәҗҗал»), Г.Монасыйпов («Имчеләр корбаны»), В.Әхмәдуллин («Кияү эзләү»), Я.Вәли («Оят, яки Күз яше», «Ачлык кушты»), төрек язучысы Н.Кәмал («Кызганыч бала») пьесалары, рус теленнән үзгәртеп эшләнгән әсәрләр (С.Турбинның «Денщик Гали», С.В.Рутковскийның «Мирас булышты» («Наследство помогло») һәм «Көнче ир» («Ревнивый муж») һ.б.) тәшкил итә. Һәр тамашаның икенче өлешендә концерт була, анда Ф.Арская шигырьләр һәм татар язучыларының чәчмә әсәрләреннән өзекләр укый, И.Кудашев-Ашказарский гармунда, мандолинада милли көйләр уйный; ш.у. бию номерлары, популяр оперетталардан куплетлар башкарыла. Труппа Урта Азия, Төньяк Кавказ, Кырым шәһәрләрендә гастрольләрдә йөри, Мәскәү, С.-Петербургта чыгышлар ясый. Казанда спектакльләр Зур драма театры бинасында бара. Труппа составында Ф.Арская, М.Кульбашева, И.Кудашев-Ашказарский, Б.Бәхтияров, Ш.Ибраһимов, С.Гаспринский була. 1915 тә Әстерханда труппа спектакльләрендә З.*Солтанов* катнаша. Гражданнар сугышы башлану б-н, труппа таркала; актёрларның бер өлеше И.Кудашев-Ашказарский б-н берлектә фронт театрларында эшли башлый.

*Әд.:* Татар совет театры. К., 1975; Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; Мортазин М., Корбангалиев М., Ченәкәй Т. Татар театры тарихыннан. К., 1996; Татар театры (1906–1926). К., 2003.

*Ю.А.Благов.*

**РОССИ́ЯДӘ 1905–07 ЕЛЛА́Р РЕВОЛЮ́ЦИЯСЕ**, беренче буржуаз-демократик рев-ция. Халык кузгалышына самодержавие һәм җәмгыять, дворян-алпавытлар һәм крәстияннәр, буржуазия һәм пролетариат, патша хөкүмәтенең бөекдержавачыл сәясәте һәм халыкларның милли бәйсезлеккә омтылышы арасындагы каршылыклар кискенәю сәбәп була. Революцион кризисның көчәюе Россиянең 1904–05 еллар рус-япон сугышында җиңелүен тизләтә. Рев-ция 2 стадиядә уза: 9 гыйнварда С.-Петербургта эшчеләрне аттырудан 1905 елгы декабрь коралы восстаниесенә кадәр — күтәрелеш, коралы восстаниенең бастырылуыннан 1907 елның 3 июнендә 2 нче Дәүләт Думасы куып таратылуга кадәр — төшү чорларын кичерә. Рев-циянең этәргеч көчләрен эшчеләр сыйныфы, крәстияннәр, милли төбәкләрдәге изелеп яшәүче халыклар, һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр һәм төрле катлау шәһәр халкы, ш.у. буржуазиянең бер өлеше тәшкил итә. Кузгалыш барышында хөкүмәт яклы, либераль-буржуаз һәм революцион-демократик юнәлештәге 3 сәяси лагерь барлыкка килә. Патшаның демократик хокуклар һәм ирекләр, законнар чыгаручы дума (к. *Дәүләт Думасы*) чакыруны вәгъдә иткән 1905 ел 17 октябрь Манифестыннан соң җәмгыятьне революцион юл б-н үзгәртеп коруга курс алган соц. партияләр самодержавиегә каршы коралы көрәшкә һәм Учредительләр җыенын чакыруга өндәүләрен дәвам итәләр, ә шул вакытта илнең акрынлап реформалашуына өмет тоткан буржуаз партияләр Манифест тәкъдимнәре б-н чикләнүгә һәм илдә конституцион монархия урнашуга ризалык белдерәләр. Әмма Манифестта игълан ителгән үзгәрешләр һәм реформалар гамәлгә ашарга өлгермәстән туктатыла. Берсе 72, икенчесе 103 көн яшәп калган 1 нче һәм 2 нче Думалар таратыла. 2 нче Думаны куып тарату һәм сайлау законының үзгәртелүе самодержавие тарафыннан 17 октябрь Манифестының бозылуын һәм реакция чоры башлануны аңлата. Илдә хөкем сөргән сәяси, икътисади, социаль һәм милли характердагы каршылыклар чишелеш тапмый.

1905–07 еллардагы рев-ция вакыйгалары Казан губернасы терр-ясендә актив җәелә. 9 гыйнварда С.-Петербургтагы тыныч демонстрациягә каршы корал кулланганнан соң, губернада стачка хәрәкәте сизелерлек көчәя. 1905 нең гыйнвар–мартында Казанда 20 дән артык эшче стачкалары уза, аларда 6500 кеше катнаша. Гыйнвар–февральдә стачка хәрәкәтенә Казан ун-ты һәм Вет. ин-ты студентлары, Казан татар укытучылар мәктәбе, шәһәр гимназия-мәктәпләре, шәһәр һәм губернаның башка уку йортлары укучылары да кушыла. Казан либераллары, җыелышлар җыеп, сәяси һәм икътисади буржуаз реформалар үткәрүне таләп иткән петицияләр тутыралар. Татар либераллары ш.у., петицияләр язып, милли мәдәният һәм мәгарифне, ана телен үстерүне, татар эшмәкәрләре һәм дин әһелләренә куелган чикләүләрнең бетерелүен таләп итәләр. 1905 нең язы һәм җәендә кузгалышта катнашучылар саны арта (Казан пристанендә, Шабановның күн з-дында, Локкеның паркет ф-касында, Алафузов пр-тиеләрендә стачкалар була), крәстияннәр хәрәкәте көчәя, көрәш рухы солдатларны да кузгата. Патша манифесты игълан ителгәннән соңгы погром һәм репрессияләргә җавап итеп, с. -д., эсерлар, Крәстияннәр берлеге вәкилләре халык милициясе һәм *Казан шәһәр коммунасы* (1905 нең 19–21 октябрендә гамәлдә була) төзергә карар итәләр. 21 октябрьдә шәһәр думасы бинасына урнашкан Шәһәр коммунасы карагруһчылар, полиция, армия һөҗүменә дучар булып тар-мар ителә. Аны саклаучы 130 кеше кулга алына. Губерна тормышының 1906 ел башындагы төп сәяси вакыйгасын 1 нче Дәүләт Думасына сайлаулар тәшкил итә. Думага сайлаулар алдыннан губернада кадетлар партиясе оешмасы (к. *Конституцион демократлар партиясе*) төзелә һәм актив рәвештә пропаганда эшен җәелдерә. Свешников, Рам, Либих з-длары, «Газ һәм электр» җәмгыяте эшчеләре сайлауларга бойкот белдерәләр, шәһәр сайлаучылары арасында сайлауларга килми калучылар проценты зур була. Шулай да сайлауларны өзү ниятләре барып чыкмый; нәтиҗәдә, Казан губернасыннан һәм Казаннан сайланган 10 депутатның 6 сы — Думаның хезмәт (трудовиклар) төркеменә (1 депутат бер үк вакытта мөселманнар төркеме әгъзасы да була), 2 се — кадетлар фракциясенә, 2 се кадетларга якын торучы мөселманнар берлегенә керә. 1906 ның 8 июлендә 1 нче Дума куып таратылганнан соң революцион чыгышлар дәвам итә, ләкин забастовка хәрәкәтенең куәте кими. 1906 да губернада 10 нан артык профсоюз оеша, 1907 нең башында алар Профсоюзлар үзәк бюросына берләшәләр. 1906–07 дә урыннардагы иҗтимагый тормышка демократик рухлы вакытлы матбугат — «Азат», «Азат халык», «Таң йолдызы», «Урал», «Вечернее эхо», «Волжский листок» («Волжский курьер»), «Волжский вестник», «Дневник Казани», «Казанский вечер», «Крестьянская газета» һ.б. зур йогынты ясый. 1906 да 148 крәстиян күтәрелеше булып уза. *Столыпинның аграр реформасы* губернаның а.х.ндагы каршылыкларын юкка чыгара алмый. Казан студентларының революцион җыелышлары һәм митинглары ш.у. дәвам итә, 1906 да Студентлар вәкилләре советы оештырыла. 1907 ел башында 2 нче Дәүләт Думасына сайлаулар уздырыла. Думага 5 трудовик (1 се мөселман-трудовик), 3 мөселманнар берлеге әгъзасы, 1 кадет үтә, ш.у. Казаннан 1 депутат урынын октябрист ала. 1906 ның октябреннән Казанда көчле сак хезмәте булдырыла, шушы бер ай эчендә шәһәр полициясе тарафыннан 40 тентү һәм кулга алулар оештырыла, демократик рухлы матбугат органнары кырыс цензурага дучар ителә, конфискацияләнә, ябыла. 1907 нең 3 июнендә 2 нче Дума куып таратылганнан соң, губернада репрессияләр көчәя, алар, башлыча, революцион партияләрнең урыннардагы оешмаларына һәм самодержавиегә оппозициядә торучы көчләргә каршы юнәлдерелә.


Чыг.: Революционное движение в Татарии в 1905–1907 гг.: Док. и материалы. К., 1957; Революция 1905–1907 гг.: Док. и материалы. М., 1975.

*Әд.:* Аросев А. Казанские очерки революции 1905 года. К., 1925; Ибрагимов Г. Татары в революции 1905 г. К., 1925; Татария в дни первой русской революции. К., 1955; Хасанов Х.Х. Революция 1905–1907 гг. в Татарии. К., 1965; шулук. Казань в годы первого штурма царизма. К., 1985; Хабибрахманова А.В. Деятельность политических партий в Казани в годы Первой российской революции. К., 2006.

*Р.А.Циунчук.*

**РОСТО́ВКА** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 25 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ютазы елгасы буенда. 2010 елда 131 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Колчевка исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында укырга-язарга өйрәтү мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 500 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Сумароково волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 231, 1889 да — 305, 1897 дә — 354, 1910 да — 325, 1920 дә — 544, 1926 да — 461, 1938 дә — 319, 1949 да — 288, 1958 дә — 226, 1970 тә — 204, 1979 да — 166, 1989 да — 91, 2002 дә — 138 кеше.

**РОСТО́ВЦЕВ** (чын фамилиясе Ростовский) Иван Алексеевич (21.8.1873, Түбән Новгород губ., Горбатов өязе Мартово а. — 15.6.1947, Ярославль ш.), актёр, режиссёр, антрепренёр, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1937), халык артисты (1944). Сәхнә эшчәнлеген Түбән Новгород театрында 1893–94 еллар сезонында режиссёр ярдәмчесе һәм икенче пландагы рольләр актёры буларак башлый; 1900 дән, Саратов шәһәрендәге халык театры б-н җитәкчелек итеп, антрепренёрлык б-н шөгыльләнә. 1903 тә Новочеркасск театры труппасының баш режиссёры. 1906 да Казанда, антрепренёр П.И.Васильевның *«Аркадия» бакчасындагы* җәйге театры труппасы режиссёры һәм 2 нче комигы. Шулай ук Владикавказ, Новороссийск, Ростов-Дон, Архангельск, Самара, Саратов, Ярославль шәһәрләрендәге театрларда да эшли. 1929–30, 1931–33, 1935–36 да Казан Зур драма театрының сәнгать җитәкчесе һәм баш режиссёры. Казан сәхнәсендә беренче тапкыр «Ату» («Выстрел», А.Безыменский), «Инга» (А.Г.Глебов), «Курку» («Страх», А.Н.Афиногенов), «Шөһрәт» («Слава», В.М.Гусев) спектакльләрен куя. М.Горькийның «Мещаннар» («Мещане») пьесасын 1929, 1932 һәм 1935 тә Казан Зур драма театрында куя. Һәр куюында пьесаның кырыс һәм реакцион консерватизм идеологиясе булган мещанлыкка каршы юнәлдерелгән фаш итү пафосын көчәйтә бара. Классикага («Төшемле урын» — «Доходное место», А.Н.Островский; «Мәкер вә мәхәббәт» — «Коварство и любовь», Ф.Шиллер) мөрәҗәгать итеп, Р. социаль каршылыкларны бөтен тирәнлеге б-н ачарга омтыла. Рус реалистик мәктәбе тарафдары буларак, Р. Казан Зур драма театры сәхнәсендә, ш.у. совет чоры репертуарын тәшкил иткән пьесаларны сәхнәләштергәндә психологизмга һәм тормыш хакыйкатенә тугрылык принципларын раслауга зур өлеш кертә.



И.А. Ростовцев.

*Әд.:* Любомудров М. Всегда — битва // Театральная жизнь. 1961. № 12; Иляловa И., Ингвар И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**РОТА́Н**, кисәүбаш (Perccottusglehni), алабугасыманнар отрядыннан кисәүбашлылар семьялыгындагы балык. Евразиянең төче сулыкларында очрый. ТР терр-ясендә Куйбышев сусаклагычында һәм аңа тоташкан агым суларда яши. 8–14 *см* озынлыкта, йомры гәүдәле, тәңкәләр б-н капланган. Корсак йөзгечләре бер-берсенә якын, төптә кушылалар. Башы һәм авызы зур, аскы казналыгы алга чыгып тора. Төсе аксылдан каралҗымга кадәр, сырты карасу-яшел, ян-яклары кара тимгелле сары төстә, йөзгечләрендә кара тимгелләр, сызыклар бар. Ата балыклар уылдык чәчү чорында кара төскә керә. Җенси җитлегү чоры — яшәвенең 2 нче елында. Уылдыгын май–июльдә чәчә. Үрчемлелеге — 1 мең уылдык бөртеге (озынча формада, үсемлекләргә һ.б. предметларга ябышкак төкчәләр ярдәмендә береләр). Ата балык ояны саклый. Р. балык маймычлары (ш.и. үзенеке б-н дә), бөҗәк личинкалары, кыслачыклар б-н туклана.

**РО́ТЕРТ** Владислав Адольфович (25.7.1863, Вильно ш., хәзер Вильнюс — 3.1.1916., Петроград), ботаник, ботаника д-ры (1893). Дерпт (хәзер Тарту) ун-тын тәмамлый (1884). 1887–89 елларда һәм 1915 тән Петербург ФАндә эшли. 1889–97 дә Казан ун-тында, 1896 дан проф. 1897 дән — Харьков, 1902–08 дә Новороссийск (Одесса ш.) ун-тлары профессоры. 1910–14 тә Краковта, Краков ФА әгъзасы (1913). Хезмәтләре үсемлекләр анатомиясе һәм физиологиясенә, аларның систематикасына карый. Яңа 8 төр тасвирлый. Үсемлекләрнең вегетатив органнарында хромосомалар булуын ачыклый. Рус телендә беренче «Үсемлекләр физиологиясе курсы» («Курс физиологии растений», 1891) һәм «Үсемлекләр анатомиясе курсы» («Курс анатомии растений», 1–2 кис., 1895–97) дәреслекләре авторы. Р.ның фототропизм буенча Казан ун-тында эшләгән чорда язылган «Гелиотропизм турында» («О гелиотропизме», 1893) хезмәте аеруча киң танылу ала.

Хезм.: О движении у высших растений. К., 1890; О строении оболочки растительных сосудов. К., 1897; Введение в физиологию растений. Хар., 1899.

*Әд.:* Манойленко К.В. Владислав Адольфович Ротерт. 1863–1916. Л., 1978.

**РОТНИ́ЦКИЙ** Семён Аронович (28.12.1915, Минск — 13.5.2004, С.-Петербург), нәкышьче, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957). 1937–41 һәм 1946–48 елларда СССР САнең И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тында укый (Б.В.Иогансон шәкерте). 1948 дән — Казан сәнгать уч-щесе директоры. 1960–83 тә В.И.Мухина исем. Ленинград югары сәнгать-сәнәгать уч-щесендә доцент. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1951). Натурадан ясалган һәм тарихи портретлар, тематик картиналар, пейзаж жанрларында эшли. Казан чорында респ-каның мәдәният һәм фән эшлеклеләре, хезмәт алдынгыларының нәкышь портретлары галереясын иҗат итә: «В.Маяковский һәм М.Горький 1915 елда Пенатта И.Е.Репин янында» (1948), «ТАССРның халык артисты Н.И.Якушенко портреты», «И.Ф.Шаляпина портреты» (икесе дә — 1949),



С.А.Ротницкий. «ТАССРның халык артисты Н.И.Якушенко портреты». 1949. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

«ТАССРның халык артисты Х.Г.Әбҗәлилов портреты» (1950), «РСФСРның халык артисты Әбҗәлилов Х.Г. портреты» (1955), «Химия фәннәре докторы профессор Г.Х.Камай портреты» (1952), «Рәссам В.И.Кудельткин» (1956) һ.б. 1960–80 дә «Россиянең бөек уллары» портретлар сериясен (А.С.Пушкин, Н.И.Лобачевский, Л.Н.Толстой, И.Е.Репин, Ф.И.Шаляпин, А.М.Горький) иҗат итә.

Күргәзмәләрдә (1939 дан), ш.и. Казан рәссамнары (1948 дән), Мәскәүдә ТАССРның



С.А.Ротницкий. «РСФСРның халык артисты Әбҗәлилов Х.Г. портреты». 1955. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.




«Рубин» футбол командасы — Россия чемпионы. 2008, 2009.

сәнгать һәм мәдәният Декадасы көннәре (1957), «Советская Россия» (1960) күргәзмәләрендә еш катнаша. Шәхси күргәзмәләре Ленинградта (1985), С.-Петербургта (1991, 1998, 2001, 2004), Блумингтон, Миннеаполис, Скотендейл шәһәрләрендә (АКШ, 1992) уздырыла.

Әсәрләре Рус музеенда (С.-Петербург), ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Чуаш сәнгать музеенда, Россия, Франция, АКШ, Германия, Финляндия, Япония һ.б. илләрдәге шәхси тупланмаларда саклана.

Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Семён Аронович Ротницкий. Выставка произведений: Каталог. Л., 1991.

**РОТЭРМЕ́ЛЬ** Зоя Адольфовна (12.8.1903, Тобол губ. Ишим ш. — 1995, Чабаксар ш.), дуңгызлар ашату һәм үрчетү белгече, а.х. фән. д-ры (1962), проф. (1964). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1927). 1928–30 елларда Сталин округының Чистяков р-нында кичке мәктәп укытучысы, 1930–34 тә Татсоюз с-зында зоотехник, 1934–36 да Татарстан дуңгызчылык трестында зоотехник, 1937–38 дә Татарстан өлкә а.х. тәҗрибә станциясендә өлкән фәнни хезмәткәр, 1938–44 тә Казан вет. ин-тында өлкән лаборант, укытучы. 1944–54 тә — Казан а.х. ин-ты, 1954–60 та Казан вет. ин-тының терлекчелек каф. доценты, 1960 та Казан а.х. ин-ты доценты, 1962–67 дә терлекчелек каф. мөдире, бер үк вакытта, 1962–67 дә, проректор. Р. терлек азыгы б-н үзләрен үзләре тәэмин итүче дуңгызчылык хуҗалыклары өчен дуңгызларны тукландыруның рациональ системасын эшли, ТАССРда дуңгызчылык тармагы буенча нәсел яңарту эшенең перспектив планын төзи.

Хезм.: Использование разовых маток в свиноводстве. К., 1956; Важнейший источник увеличения производства свинины // Сельское хозяйство Татарии. К., 1958; Влияние разных типов кормления при промышленном скрещивании свиней // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1959. Т. 71.

*Г.С.Шәрәфетдинов, Р.Ш.Әскәров.*

**«РО́ЧНИК ТАТА́РСКИ»** («Rocznik tatarski» — «Татар елъязмасы»), бюллетень. *Речь Посполита татарларының мәдәни-агарту берлеге* органы. Польшада поляк телендә нәшер ителә (1–3 т., 1932, 1935, 1938). Мөхәррире — Л.*Крычыньський*, редколлегиягә М.Александрович, А.Воронович, О.Крычыньский, С.*Крычыньский* керә. Редколлегия әгъзалары мәкаләләреннән тыш И.Ахматович, С.Дзядулевич, Т.Ковальский, Т.Станиш, Т.Стрыкевич-Кожон, С.Шапшал, Я.Шынкевич һ.б. материаллары басыла. «Р.т.»ның чыга башлавы Польша шәркыятьчеләр җәмгыятенең 2 нче съезды ачылуга туры килә. Мәкаләләрнең күп өлеше Польша татарлары тарихына, ш.и. аның Речь Посполита тарихына бәйле булган аз билгеле вакыйгаларына багышлана. Бюллетень фактик материалга һәм беренче тапкыр басылган тарихи чыганакларга бай, ш.у. анда этнография, дини тормыш, матди культура буенча, татарларның иҗтимагый-сәяси тормышына караган белешмәләр күп. 3 нче томда С.Крычыньскийның «Литва татарлары. Тарихи-этнографик анализ омтылышы» («Литовские татары. Попытка историко-этнографического анализа») монографиясенең бер өлеше басыла; текстка мәчетләр, зиратлар, татар авыллары, дини йолалар сурәтләнгән фотолар, ш.у. Төньяк-көнчыгыш Польшаның татарлар яши торган авыллары күрсәтелгән картасы бирелә.

*Әд.:* Гришин Я.Я. Польско-литовские татары: взгляд через века: Ист. очерки. К., 2000.

**РСФСР**, к. *Россия Федерациясе.*

**«РУБИ́Н»**, футбол командасы, 2008, 2009 елларда футбол буенча РФ чемпионы. 1958 елда оештырыла. Исеме берничә тапкыр үзгәртелә: 1958–64 тә «Искра», 1965–91 дә һәм 1993 тән «Рубин», 1992–93 тә Казан авиация җитештерү берләшмәсе каршында «Рубин-Тан», 1995 тән «Рубин» футбол клубы» муниципаль учреждениесе. 1958–65 тә РСФСР чемпионатының «Б» классында, 1966–69 да, 1972–74 тә, 1978–91 дә СССР чемпионатының 2 нче лигасында, 1970–71 дә, 1975–77 дә 1 нче лигасында, 1992–93 тә Россия чемпионатының 1 нче, 1993–97 дә 2 нче лигасында; 1998–2000 дә 1 нче дивизионында, 2003 тән Премьер-лигасында. Баш тренерлары — Н.И.*Сентябрёв* (1959–71), А.А.Берючевский (1978–80), В.А.Михайлов (1981–87), А.А.Семёнов (1988), Р.Г.Наврозов (1989), М.В.Задикашвили (1989–95), И.В.Золотухин (1990–91), А.В.Ивченко (1992), В.А.Лукашенко (1993), И.С.Волчок (1996–98), М.Раданович (1998 нең мае), А.С.Ирхин (1998 нең июненнән), П.Ф.Садырин (1999), В.П.Антихович (2000–01),

А.Д.Афонин (2001 нең июле), К.Б.Бердыев (2001–13), В.А.Маминов (2014 нең гыйнвар–мае), Р.С.Билалетдинов (2015 нең февраль–сентябре), В.А.Чалый (2014, 2015–16), Х.Грасия (2016 дан). Иң югары казанышлары: Россиянең 1 нче дивизионында җиңүче (2002, Премьер-лигага чыгу), Россия чемпионатларында бронза медаль алучы (2003), җиңүче (2008, 2009), Россия кубогы финалисты (2008/09), Ла Манг Кубогы иясе (2005, 2006); Европа турнирларында: УЕФА Кубогы (2004/05, 2006/07), Интертото Кубогы (2007) ярышларында, Чемпионнар лигасында, УЕФАның Европа лигасында (2009/10) катнаша. Россия суперкубогы (2010, 2012), Дуслык (2010) һәм Россия (2012) кубоклары иясе.

*Әд.:* М а к а р о в А.Д. «Рубин» (Казань): История и статистика. 1958–2000. К., 2001.

**РУБРУ́К** (Rubrouck, Roebroeck) Вильгельм де Гильом (1215–20 еллар арасы — 1270 тирәсе), Фламанд сәяхәтчесе, монах. Фландриядә туа. Миноритлар борадәрлеге монахлары ордены әгъзасы. Франция короле Людовик IX га (1226–70) хезмәт итә. 7 нче Тәре походында катнаша. Мисырда тәре йөртүчеләр тар-мар ителә, Франция короле әсир төшә. Әсирлектән азат ителгәч, Людовик IX Кипрда ныгып урнаша һәм Мисыр мәмлүкләренә каршы яңа килешү төзергә җыена; король боерыгы б-н Р. әлеге килешүне төзү максатында Монголиянең бөек каһанына җибәрелә. Илчелек — Константинополь шәһәренә, аннан Кырымга китә. 1253 елның маенда Солдайя (Судак) Кырым портына килгәч, Р., ике монах б-н Кырым һәм Кара диңгез буе далалары аша узып, *Сартак хан*, аннан соң Иделдә *Бату хан* станына юнәлә. Бату хан Көнбатыш илләре б-н килешү төзүдән баш тарта һәм христиан динен таратуга каршы чыга. Р. *Каракорым* шәһәренә бөек каһан Мөнке янына китә. 1953 нең декабрендә Монголиягә килә. Җавап көтеп, 3 ай — Бөек каһан ставкасында, 2 ай Каракорымда яши. 1254 нең июнендә кабат Европага кайта. Людовик IX сараена әйләнеп кайткач, «Көнчыгыш илләренә сәяхәт» («Путешествие в восточные страны», Европа телләрендә нәшер ителә; Россиядә А.И.Малеин тәрҗемәсендә басыла, СПб., 1910) исемле китап яза. Анда монголлар яулап алган дәүләт һәм халыкларга, ул халыкларның монголларга каршы көрәшенә кагылышлы кыйммәтле мәгълүматлар тупланган; Р. *Алтын Урда* идарәчеләре һәм Монголия бөек каһаннарының үзара мөнәсәбәтләре, Мөнке ставкасы, Каракорым шәһәре, монголларның гореф-гадәтләре, көндәлек тормышлары, кораллануları турында яза. Дипломатик вазифаны үтәгәннән соң, Парижда король сараенда кала. 8 нче Тәре походы вакытында үлгән дип фараз ителә.

Х е з м.: The texts and versions of J. de Plano Carpini and William de Rubruquis L., 1903; Der Bericht des Franziskaners Wilhelm von Rubruk uber seine Reise in das innere Asiens in den Jahren 1253–1255. Lpz., 1925.

*И.Л.Измайлов.*

**РУБЦО́В** Виктор Иванович (5.6.1939, Краснодар краеның Тимашевский р-ны Тимашевская станицасы), архитектор, ТАССРның атказ. архитекторы (1986). Мәскәү архит-ра ин-тын тәмамлый. 1967–2000 елларда «Татагропромпроект» ин-тының баш архитекторы. ТР (1972–2000), РФ (1996 дан) Архитекторлар берлекләре идарәләре әгъзасы (1972–2000). Бер үк вакытта, 1968–82 дә, Казан төзүче инженерлар ин-тында укыта, 1993–2000 дә шәхси иҗат остаханәсен җитәкли. Татарстан, Удмурт Респ-калары, Пенза, Кострома һәм Төмән өлкәләрендәге авыл торак пунктлары төзелешләренең 700 дән артык генераль план һәм проекты, тәҗрибә рәвешендә салынган 20 торак йорт, гражданлык әһәмиятенә ия 80 объект проектының авторы. Кукмара р-нының Югары Өскебаш авылы (1970), Тукай р-нының Яңа посёлогы (1981), Лаеш р-нының Габишев авылы (1986), Азнакай р-нының Чаллы авылындагы (1987) төзелеш проектлары — СССР ВДНХсы дипломнары, Габишевтагы тәҗрибә рәвешендә салынган торак йортлар проектлары сериясе РСФСР Дәүләт төзелеш к-тының 1 нче дәрәҗә дипломы б-н бүләкләнә (1986).

**РУБЦО́В** Владимир Анатольевич (25.9.1957, Казан), икътисади геогр. белгече, геогр. фән. д-ры (2004), проф. (2007). РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1980), шунда ук эшли, 2005 тән икътисади геогр. һәм төбәкара анализ кафедрасы (2015 тән Идарә, икътисад һәм финанс ин-тының сервис һәм туризм кафедрасы) мөдире. Хезмәтләре географиядә матем. алымнарга, төбәкара планлаштыру һәм фаразлауга, халык һәм аның урнашу географиясе, рекрацион география һәм туризмга карый. Р. терр-ль системаның үсеш тигезлеге концепциясен эшли (Татарстан Респ-касы мисалында).

Х е з м.: Региональный геоэкологический анализ. К., 2005 (автордаш); Модель устойчивого развития // Математика в географии (вчера, сегодня, завтра). К., 2006; Математико-картографические методы в демографических исследованиях. К., 2010 (автордаш); Геодемографический потенциал Республики Татарстан. К., 2014 (автордаш); Территориальные аспекты развития туризма в Республике Татарстан. К., 2014 (автордаш).


**РУБЦО́ВА** Риоритта Александровна (21.1.1941, Казан), кинодраматург, сценарийлар авторы, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1984). Бөтенсоюз дәүләт кинематография ин-тының сценарий ф-тын тәмамлый (1966, И.В.Вайсфельд остаханәсе). 1965 елдан Казан телевидение студиясендә яшьләр тапшырулары мөхәррире, 1969 дан җитештерү буенча баш мөхәррир. «Бии Галина Калашникова» («Танцует Галина Калашникова», 1966), «Күңелдә яз» («В душе весна», 1969) фильмнарының сценарий авторы. 1970 тән Р. кинорежиссёр В.И.Беспалов б-н берлектә «Татар гармуннары» («Татарские гармошки», 1970), «Нәҗип Җиһанов музыкасы» («Музыка Назиба Жиганова», 1972), «Кояш яктырткан наратлар» («Сосны, освещённые солнцем», 1973), «Кырлай» (1974), «Сабан туе буяулары» («Краски Сабантуя», 1976), «Кер минем ак йортыма» («Войди в мой белый дом», 1978) фильмнарын төшерә. Р.ның В.И.Беспалов б-н иҗади берлектәге КамАЗ турында «Яр Чаллы. Шәрехләмәләр белән портрет» («Набережные Челны. Портрет с комментариями», 1972), «КамАЗ. Икенче сулыш» («КамАЗ. Второе дыхание», 1980), «... плюс йөрәк» («... плюс сердце», 1982), «Килешү акчадан кыйммәтрәк» («Договор дороже денег», 1984) фильмнары, ш.у. Татарстанның мәшһүр музыкантларына багышланган «Күңел моңы» («Мелодия души», 1990, С.Сәйдәшев турында), «Бу мәңгелек могҗиза» («Это вечное чудо», 1993, Р.Урасин турында), «Рөстәм Яхин. Сентименталь сәяхәт» («Рустем Яхин. Сентиментальное путешествие», 1993) фильмнары циклы аерым урын тота. Р. сценарийлары буенча «Татар милли бүләге» («Татарский сувенир», 1975), «Рөстәм Яхин көйләре» («Мелодии Рустема Яхина», 1981), «Тавлин чишмәсе» («Тавлинский родник», 1981), «Казан шәһәре — нык шәһәр» («Град Казань зело крепок», 1991), «Марсель Сәлимҗанов. Йөрәкләрдә кала эзләр» («Марсель Салимжанов. Оставить в сердце след», 1995), «Александр Ключарёвны искә алып» («Вспоминая Александра Ключарёва», 1996), «Академик Мансур Хәсәнов» (2003), «Алмаз Монасыйпов. Казаным, Казаным...» (2004), «Тукай төшләре» («Сны Тукая», 2006), «Алабуга. Кама буе хәзинәсе» («Елабуга. Жемчужина Прикамья», 2006), «Ринат Еникиев. Хәзер яки беркайчан да» («Ренат Еникеев. Сейчас или никогда», 2007) һ.б. фильмнар төшерелә. Р. сценарийлары буенча төшерелгән күп кенә фильмнар бөтенсоюз телевизион һәм документаль фильмнар фестивальләре дипломнары һәм призлары б-н бүләкләнә; «Советларча яшәү рәвеше» («Советский образ жизни») фильмы сценарие ТАССРның Х.Ямашев исем. Журналистлар берлеге бүләгенә лаек була (1980). Р. сценарийлары буенча төшерелгән 60 ка якын фильм Татарстан кинематографының алтын фондына керә.

Х е з м.: Кинохроника һәм видеотехника — конкуренты или союзники? // Перспективы развития современного общества: искусство и эстетика: Материалы Всерос. науч. конф. К., 2003 (автордаш); Рэм Урасин. Уроки музыки // Казань. 2003. № 3; Весточка с войны // Казань. 2003. № 5/6; Рустем Яхин в воспоминаниях современников. К., 2004 (автордаш).

*Е.П.Алексеева.*

**РУГО́ТИН** Григорий, к. *Гурий*.

**РУДА́ БУЛМАГА́Н ФАЙДАЛЫ́ КАЗЫЛМАЛА́Р ГЕОЛО́ГИЯСЕ ҮЗӘ́К ИНСТИТУТЫ́**, Р Ф Табигать байлыклары һәм экология министрлыгының һәм Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыгының фәнни-тикшеренү институты («ЦНИИгеолнеруд»), федераль дәүләт унитар пр-тиесе. СССР ФАнең Казан ф-лы буларак 1945 елда оештырыла, 1963 тән Геол. буенча СССР Дәүләт ком-тының Геол. ин-ты, 1972 дән СССР Геол. министрлыгының Бөтенсоюз руда булмаган файдалы казылмалар фәнни-тикшеренү ин-ты, 1999 дан хәзерге исемендә. 1993 тән ТР ФАнең фәнни-методик җитәкчелегендә. Институтта 2 фәнни үзәк (геол.-икътисади, аналитик-технол.) һәм җитештерү-техник база бар. Инсти-



А.П. Рудаков.

тут составында Руда булмаган файдалы казылмалар тәҗрибә-методик экспедициясе (1971–84), Ереван һәм Ташкентта тәҗрибә-методик бүлекчәләре (1973–83) була. Фәнни юнәлеше — нигездә, каты руда булмаган файдалы казылма чыганакларны ачыклау, эзләү, бәяләү һәм геол.-эзләнү эшләрен фәнни-методик яктан тәэмин итү. Күпчелек металл булмаган казылмаларның барлыкка килү процессы, утырма бассейнның төрле типларында аларны локальләштерү шартлары өйрәнелә. Төп чыганакларны ачыклау һәм эзләүнең методик нигезләре (Ю.В.Баталин, У.Г.Дистанов, А.С.Михайлов, В.Г.Чайкин һ.б.), палеобассейн һәм руда барлыкка килү процессларының геол.-геохимик модельләре эшләнә. СССРда — цеолитларның (СССР хөкүмәте бүләге, 1990; У.Г.Дистанов, А.С.Михайлов һ.б.), ТРда яңа һәм традицион булмаган файдалы казылмаларның (ТР Дәүләт бүләге, 1998; У.Г.Дистанов, И.В.Дьячков, А.В.Шишкин һ.б.) чимал базасы булдырыла, ТРда руда булмаган файдалы казылмаларны нәтиҗәле куллануның минерал.-технол. чишелешләре эшләнә (ТР Дәүләт бүләге, 2003; В.Ф.Горбачёв, Т.П.Конюхова, Т.З.Лыгина һ.б.). ТР терр-ясенең геол. төзелешенә җентекле характеристика бирелә (ТР Дәүләт бүләге, 2005; Е.М.Аксёнов, С.О.Зорина һ.б.), Идел-Кама төбәгенең (В.И.Аверьянов, У.Г.Дистанов, Н.В.Кирсанов, В.Н.Незимов һ.б.) һәм Рус платформасы утырма тышлыгының рифей-венд утырмаларының (Е.М.Аксёнов, Л.Ф.Солонцов һ.б.) стратиграфик схемалары эшләнә. Рус платформасында авлакоген типлары билгеләнә (Р.Н.Вәлиев). СССР, РФ терр-яләренең геол.-икътисади (ТР Дәүләт бүләге, 1995; Р.К.Садыйков, И.Н.Тихвинский, И.Л.Шаманский һ.б.), СССРның фосфат һәм тау техникасы чималының төп төрләрен алдан ачыклау — минерагеник, СССРның Европа өлешендәге Көнчыгышның — тектоник (Е.М.Аксёнов, Б.С.Касыймов, Э.Х.Рәхмәтуллин һ.б.), җир кабыгының эчке төзелешенең — геофизик (40–45 *км* га кадәр тирәнлектә; Г.Е.Кузнецов, А.Г.Салихов, И.М.Уразаев һ.б.), гидрогеол., Урта Идел буенең инженерлык-геол. (М.С.Кавиев, А.И.Азизов, Е.Ф.Станкевич) һ.б. карталары төзелә. Руда булмаган файдалы казылма чыганакларның (Е.М.Аксёнов, Г.Г.Ахманов, У.Г.Дистанов, О.Б.Кузнецов, А.А.Сабитов, В.А.Тимесков, А.И.Шевелёв һ.б.), күмер (А.П.Блудоров, А.В.Шишкин, Г.Н.Шубаков) һәм углеводородларның (Б.М.Йосыпов, В.А.Лобов, Н.Б.Вәлитов һ.б.) урнашу законлыклары нигезләнә. Утырма тышлык токымнарының физик үзлекләренең (ш.и. коллектор һәм палеомагнит) аерымлыклары ачыклана (В.В.Власов, А.И.Кринари, Р.Ш.Харитонова һ.б.). ТРның көнбатыш районнарын — геол. (С.О.Зорина, В.Г.Суховерков һ.б.), ТР терр-ясен — геол.-экологик (А.А.Озол) һәм Казан терр-ясен радиометрик җентекле төшерү үткәрелә. Минераль чималның фаза һәм элемент составы, чыгару технологиясе, металл булмаган казылмаларны баету һәм эшкәртүнең стандарт үрнәкләре эшләнә; минераль чимал һәм аның компонентлары нигезендә әзер продукция җитештерүдә техник шартлар һәм технол. регламентлар булдырыла, яңа төзелеш материаллары алына (А.К.Вишняков, А.П.Корнилов, В.П.Лузин, Т.З.Лыгина, Р.А.Хәйдәров һ.б.). Файдалы казылмаларның 40 төре буенча таудан казып чыгару һәм тау токымнарын эшкәртү пр-тиеләренең мәйдан һәм чыганакларны алдан ачыклау өчен мәгълүмат базалары һәм банклары булдырыла; чималның конъюнктурасы, импорты, экспорты, металл булмаган казылмаларның матди составы, технол. үзлекләре һәм эшкәртү ысулларына сыйфатлама буенча; компьютер программалары пакеты; Россия һәм аерым төбәкләр (ш.и. ТР) буенча һәм «Россиянең металл булмаган казылмалары» («Неметаллы России», Р.Ф.Вафин, В.А.Васерман, Л.П.Лашкова, Д.Семанов һ.б.) дәүләт мәгълүмати системасы өчен геодинамик, минерагеник, геол.-икътисади цифрлы карталар атласы эшләнә. Россиянең җир асты байлыкларын өйрәнү һәм минерал.-чимал базасын кабат җитештерү («Металл булмаган файдалы казылмалар»); РФнең минерал-чимал базасын (агрохимия, тау химиясе, тау техникасы, руда булмаган металлургия чималы) геол. өйрәнү, кабат җитештерү һәм куллану стратегик программалары: металл булмаган казылмаларның чимал базасын кабат җитештерү буенча РФнең табигать ресурслары һәм экология министрлыгының геол.-эзләнү эшләре буенча озак сроклы дәүләт программасы (2005–2010 һәм 2020 гә кадәр) эшләнә. Файдалы казылма чыганакларның (ш.и. нефтьнең) геологиясе, геол.-икътисади, аналитик-минералогик һәм технол. өйрәнүләр, руда булмаган чималны бәяләү һәм эшкәртү буенча Халыкара һәм Бөтенроссия конференцияләре уза. Институт 20 дән артык ерак һәм якын чит илләргә фәнни һәм методик ярдәм күрсәтә. «ТАССРның руда булмаган минераль ресурслары» («Нерудные минеральные ресурсы ТАССР», 1982), «СССРның металл булмаган файдалы казылмалары» («Неметаллические полезные ископаемые СССР», М., 1984), металл булмаган казылмалар өчен «Минераль чимал» («Минеральное сырьё», М., 1997–99) сериясеннән 32 чыгарылыш белешмәлекләре; «Татарстан Республикасының каты руда булмаган файдалы казылма чыганакларын эзләү, бәяләү һәм разведкалау буенча методик кулланма» («Методическое руководство по поискам, оценке и разведке месторождений твёрдых нерудных полезных ископаемых Республики Татарстан», 1–3 кис., 1999–2001) һ.б. басыла. Уйлап табуга 130 дан артык авторлык таныклыгы һәм патент алынган. Институт ТРның Мактау грамотасы (1995), ТР Президентының Рәхмәт хатлары (2005, 2010) һ.б. б-н бүләкләнә. Хезмәткәрләр саны — 260 тан күбрәк (2013), шуларның 10 сы фән д-ры һәм 50 се фән канд. Директорлары: Л.М.*Миропольский* (1945–63), А.И.*Кринари* (1963–84), Н.Н.*Ведерников* (1984–2003), Е.М.*Аксёнов* (2003 тән).

*Әд.:* Геология — жизнь моя...: Сб. очерков и воспоминаний. М., 2011. Вып. 24.

**РУДАКО́В** Александр Иванович (4.11.1938, Казан), а.х. җитештерүен механикалаштыру өлкәсе белгече, техник фән. д-ры (2004), проф. (2005), ТРның атказ. механизаторы (1997). 1966 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, «Вакуummаш» фәнни-тикшеренү ин-тында вакуум техникасын перспектив проектлау секторы башлыгы. 1969–76 да Казан технол. ун-тының гидравлика кафедрасында. 1976 дан Казан аграр ун-тында, проректор (1993–97), а.х. җитештерүен электрлаштыру һәм терлекчелекне механикалаштыру каф. мөдире (1996–2011), агробизнеста машиналар һәм җиһазлар каф. профессоры (2011 дән). Хезмәтләре а.х. техникасының пульсацияле һәм агым ясаучы җайланмаларында ярым сыек, сыек һәм газсыман тирәлекләр теориясенә, аларны исәпләү һәм күчерү алымнарына карый. Р. җитәкчелегендә газсыман тирәлекләрне күчерү өчен пневмотранспорт җайланмалары (Бессонов компрессорлар з-дында сериялэп җитештерелә, Пенза ш.); ярым сыек терлек азыгы әзерләү һәм тарату өчен автомат линия («Камгэсэнергострой»да гамәлгә кертелгән); сыек һәм газсыман тирәлекләрне агымлап катнаштыру җайланмалары (ТРның «Сельхозхимия» АҖ пр-тиеләрендә әзерләнә һәм кулланыла) эшләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2011). Уйлап табуга 25 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, «СССРның уйлап табучысы» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Механизация приготовления и раздачи влажных кормов на малых свинофермах. К., 1995; Современные принципы разработки и совершенствования технических объектов в животноводстве. К., 2002; Низковакуумные струйные аппараты. К., 2008.

**РУДАКО́В** Александр Павлович (6.10.1912, Бөгелмә ш. — 14.2.1979, шунда ук), Сов. Союзы Герое (15.1.1944), кече лейтенант. Танк уч-щесен (1942) тәмамлый. Барнаул станциясе депосында паровоз машинисты ярдәмчесе булып эшли. 1934–36 елларда һәм 1941 дән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 95 нче танк бригадасының 142 нче танк батальонында танк командиры (65 нче армиянең 9 нчы танк корпусы). Дон, Үзәк һәм Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Сталинград сугышында (1942–43), Чернигов-Припять (1943), Гомель-Речица (1943) һәм Белоруссия (1944) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Днепр елгасын кичеп, шәһәр тибындагы Лоев посёлогы (Белоруссия ССР, Гомель өлкәсе) янында батырлык күрсәтә: 1943 нең 20 октябрь төнендә Р. тан-

кы батальон составында елганы кичеп чыга һәм елганың уңъяк яр плацдармын яулап ала, Городок һәм Стародубка авылларын азат итүдә катнаша (дошманның барлык һөҗүмнәре кире кайтарыла, берничә дистә солдаты юк ителә). 1946 дан запаста. Туган ягына кайта, тимер юл депосында эшли. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Бөгелмәдә бер урам Р. исемен йөртә. Геройлар аллеясында Р.ка бюст куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000. *М.З.Хәбибуллин.*

**РУДЕ́НКО** Гөлзада Рәкыйп кызы (30.8.1956, Арча р-ны Үрнәк пос.), музей эшлеклесе, ТР һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1998, 2008). Алабуга пед. ин-тын тәмамлый (1978). 1978–86 елларда Чаллы шәһәрендә комсомол һәм партия эшендә. 1991 дән «Эврика» шәһәр мәдәният үзәге директоры, 1999–2001 дә Чаллы мәдәният һәм сәнгать идарәсе башлыгы. 2002 дән Алабуга тарих-архит-ра һәм сәнгать музей-саклаулыгы ген. директоры. Р.ның эшләү дәверендә яңа экспозицияләр булдырыла; музей-саклаулык составында яңа музейлар ачыла, аларга йөрү арта. Европа музей форумында Алабуга музей-саклаулыгына «Елның Европа музее» мактаулы исеме бирелә (2010). Алабугада музей комплексын оештырган һәм мәдәни мирасны саклауга зур өлеш керткән өчен, РФнең Мәдәният өлкәсендә хөкүмәт бүләгенә лаек була (2009). Медаль б-н бүләкләнә.

**РУДЕ́НКО** Константин Александрович (2.10.1967, Казан), тарихчы, археолог, тарих фән. д-ры (2005). Казан ун-тын тәмамлый (1992). 1993–97 елларда ТР МКның Тарихи һәм мәдәни истәлекләрне саклау буенча баш идарәсендә. 1997 дән ТР Милли музеенда, 2004 тән археол. бүлеге мөдире; бер үк вакытта, 2005 тән, ТР МК каршындагы Өстәмә белем бирү ин-тының музей эше һәм истәлекләрне саклау каф. мөдире. 2007 дән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында, каф. профессоры (2011 дән). Актаныш, Алексеев, Буа район тарихи-төбәкне өйрәнү музейларының борынгы һәм урта гасырлар тарихы экспозицияләре авторы. Хезмәтләре Идел-Кама буеның урта гасырлар тарихына, Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урданың матди мәдәниятен өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Материальная культура булгарских селищ низовий Камы XI–XIV вв. К., 2001; Тюркский мир и Волго-Камье в XI–XIV вв. К., 2001; Железные наконечники стрел VIII–XV вв. из Волжской Булгарии. К., 2003; Волжская Булгария в XI — начале XIII в.: поселения и материальная культура. К., 2007.

**РУЗА́ЕВКА РАЙОНЫ́**, РФдә. *Мордва Республикасының* үзәгендә урнашкан. 1928 елның 16 июлендә оештырыла. Мәйданы — 1089,5 *км²*. Үзәге — Рузаевка шәһәре. Халкы — 65080 (2013), татарлар — 4906 (2010) кеше. Татарлар Пешлә (Татар Пешләсе, 2340 кеше), Өрләдем, Үгенә, Татар Шебдасы авылларында тупланып яшиләр. Р.р. — элек-электән татарлар яши торган районнарның берсе. Аларның борынгы бабалары Темников Мещёрасында 11–15 йөзләрдә үк яшәгән. Хәзерге татар торак пунктлары 17 йөздә Инсар һәм Атемар-Инсар чик буе сызыгы төзелешенә бәйле рәвештә барлыкка килә. 1631 дән Урузаевка (хәзер Рузаевка ш.) һәм Пешлә, 17 йөз уртасында Өрләдем, Татар Шебдасы авылларына нигез салына, 1706 дан Үгенә авылы телгә алына. Р.р. терр-ясендә иң зур тарихи татар авылы — Пешлә. 1864 тә анда 4 мәчет эшли; 1913 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча, 584 хуҗалык исәпләнә (аларда 3607 кеше яши); 3 мәктәп һәм мәдрәсә, 5 икмәк саклау-сату кибете, 1 — нефть б-н эшләүче двигательле һәм 8 җил тегермәне, 3 май язу йорты, ярма яргыч, 4 тимерчелек, 2 янгын сүндерү машинасы эшли. Хәзерге вакытта Пешлә авылы урта мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла. Мәктәп каршында «Чишмә» фольклор ансамбле эшли; 2004 тә Ш.*Камал* музее ачыла (күренекле татар язучысы Пешләдә туа, 1906 да мәдрәсәгә нигез сала, соңрак ул мәдрәсә мәктәп итеп үзгәртелә), аның хөрмәтенә мемориаль такта урнаштырыла, шул ук елны туган нигезендә язучыга һәйкәл куела. Авылда «Мәхәллә» дини оешмасы, 2 мәчет (1995 һәм 2005 тән) эшли. Өрләдем авылында мәчет (1996 дан) бар.

*Әд.:* З и н ю к о в Р., С и р а ч ё в В. Краткие заметки о тат-пишленских татарах // Рузаевская газета. 1998. № 77, 80, 85, 87, 89, 91; Ж у р а в л ё в а Л. Татарская Пишля // Рузаевская газета. 1998. № 83; Рузаевка: История и современность. Люди и судьбы. Саранск, 2004; Татарская Пишля: Некоторые архивные данные // Татарская газета. 2004. № 1. *Ф.А.Шамонова.*

**РУ́ЗСКИЙ** Михаил Дмитриевич (7.9.1864, Петербург губ., Гдов өязе Осьмино а. — 16.4.1948, Томск ш.), зоолог, зоология д-ры (1908), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1934). Казан ун-тының физика-матем. ф-тын тәмамлый (1888), шунда ук эшли. 1901–07 елларда Казан вет. ин-тының зоол. һәм чагыштырма анатомия кафедрасында. Казан шәһәр музеен оештыручыларның берсе, табигыять тарихы бүлеге директоры (1908–13). 1913 тән Томскида: Томск ун-ты (1948 гә кадәр) һәм Томск пед. ин-ты (1936–39) профессоры, зоол. һәм чагыштырма анатомия кафедралары мөдире; бер үк вакытта Томск ун-тының зоол. музее мөдире (1948 гә кадәр), Томск ун-ты каршындагы Биол. фәнни-тикшеренү ин-тының зоол. лаб-ясе мөдире (1935–41), Себер хатын-кызлар курслары профессоры (1920 гә кадәр). Себерне өйрәнү ин-тын оештыручыларның берсе (1919–1920), зоологларның Себер фәнни мәктәбен һәм Себер зоол. җәмгыятен нигезләүче (1933). Хезмәтләре Казан, Сембер, Түбән Новгород, Вятка һәм Самара губерналары фаунасын өйрәнүгә карый. Беренчеләрдән булып, бу терр-яләрнең җир-су хайваннары һәм сөйрәлүчеләр исемлеген, Казан губернасы кошларының тулы исемлеген бастырып чыгара. Илнең төрле төбәкләренә һәм чит илләргә 25 тән артык фәнни экспедиция оештыра; Казан ун-тының зоол. музеена 439 данә кош алып кайта. Кырмыскаларның 137 яңа төрен тасвирлый, балыкларны, югары төзелешле умырткалыларны, бигрәк тә кошларны кертеп, гидробионтларны тикшерә. «Россия кырмыскалары» («Муравьи России», т. 1–2, 1905–07) монографиясе авторы. Казан ун-ты каршында Табигыятьчеләр җәмгыятенең К.Ф.Кесслер исем. (1894), Петербург ФАнең К.М.Бэр исем. (1908), Мәскәү табигыять фәнен яратучылар, орнитология һәм этнография җәмгыятенең А.П.Богданов исем. (1908) бүләкләре иясе. 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 2 нче дәрәҗә Изге Станислав, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Бассейн реки Свияги и его рыбы // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Имп. Казан. ун-те. 1887. Т. 17, вып. 4; Вредные насекомые Казанской и Симбирской губерний в 1889 г. К., 1889; Материалы к изучению птиц Казанской губернии. К., 1893; Результаты исследования земноводных и пресмыкающихся в Казанской губернии и местностях с нею смежных. К., 1894. *В.И.Гаранин.*

**РУКАВИ́ШНИКОВ** Виктор Алексеевич (31.1.1952, Ульянов ш.), химик-технолог, пед. фән. д-ры (2004). 1974 елда Казан технол. ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: 1974–80 дә гидравлика кафедрасында; 1981 дән Идарә, автоматлаштыру һәм мәгълүмат технологияләре ин-тының инженерлык компьютер графикасы һәм автомат проектлаштыру кафедрасында, проф. (2004 тән). 2008 дән Казан энергетика ун-тының инженерлык графикасы каф. мөдире. Хезмәтләре үзле һәм аномаль үзле сыеклыкларның күчәр симметрияле кәкресызыклы өслекләр буйлап нәзек катламлы агымнары гидродинамикасы өлкәсенә карый. Р. сыеклык агымы җәелү процесссын теоретик яктан хәл итә һәм тикшерә. Газ-тузаннан чистарту аппаратларында кулланыла торган бәрмә типтагы дисперслаучы җайланманың параметрларын исәпләү методикасын эшли (илнең төрле шәһәрләрендә 250 дән артык аппарат гамәлгә кертелә). Югары техник уку йортларында булачак инженерларны укыту өчен яңа компьютер технологияләрен тәкъдим итә. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Осесимметричное растекание струи аномально-вязкой жидкости по поверхности тел вращения // Инженерно-физ. журн. 1982. Т. 42, № 6 (автордаш); Разбрызгивающее устройство с неподвижными криволинейными поверхностями // Промышленная и санитарная очистка газов. 1983. № 2 (автордаш); Геометрическое моделирование как методологическая основа подготовки инженера. К., 2003.

**РУКАВИ́ШНИКОВА** Ольга Михайловна (13.3.1955, Архангельск өлкәсенең Молотовск, хәзер Северодвинск ш.), спортчы (җиңел атлетика, күптөр көрәш), Россиянең атказ. спорт остасы (2003). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1979). Спорт б-н 1968 елда шөгыльләнә башлый, тренеры — Ю.М.*Красильников*. «Буревестник» ирекле спорт җәмгыятендә (Казан) тәрбияләнә. РСФСР (1972, 1975, 1978, биеклеккә сикерү), РСФСР халыклары спартакиадалары (1975, 1979), СССР (1974, яшүсмерләр, күптөр ярыш; 1977, озынлыкка сикерү) чемпионы, СССР–ГФР матчында җиңүче (1973, яшүсмерләр, күптөр ярыш), СССР җыелма командасы составында Европа кубогы иясе (1977, күптөр ярыш), СССР чемпионатында (1977, озынлыкка сикерү; 1980, күптөр ярыш), Олимпия уеннарында (1980; күптөр


С.Я. Румовский.


А.И. Румянцев.

ярыш нәтиҗәсе — 4937 очко, иң кыска вакытлы дөнья рекорды буларак, Гиннесс рекордлар китабына кертелә, 0,4 *с* дәвам итә) көмеш медаль ала. СССР рекордсмены (1973, яшүсмерләр, күптөр ярыш, озынлыкка сикерү; 1980, озынлыкка сикерү). 1994 тән Мәскәүдә.

**РУЛЬ** Леонард Константинович (28.10.1957, Пермь өлкәсенең Александровск р-ны Яйва а.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). 1980 елда Урал политехник ин-тын тәмамлаганнан соң, «Камаз» ЖБнең Кою з-дында мастер, участок башлыгы, цехның өлкән мастеры булып эшли. 1986 дан «Алабуга автомобиль заводы» ЖБ» АҖдә: цех башлыгы, баш инженер урынбасары (1993 тән), станок-инструментлар з-дының җитештерүне әзерләү һәм үстерү хезмәте җитәкчесе (2003 тән), инженерлык үзәгендә директор урынбасары (2009 дан). Дәүләт бүләге 50–80 *т* йөк күтәрешле нефть һәм газ скважиналарын ремонтлау һәм үзләштерү өчен югары техникалы күтәрү агрегатларын эшләүдә һәм җитештерүдә катнашканы өчен бирелә.

**РУМИ́** Җәләлетдин (30.9.1207, Әфганстан, Бәлх ш. — 17.12.1273, Төркия, Конья ш.), шагыйрь, суфи шәех, философ. Фарсы һәм төрки телләрдә язган. Атасы — күренекле дин галиме Баһаветдин Вәләд сәлҗүк солтаны Галәветдин Кәй-Кубадка хезмәт итә. Атасы вафатыннан соң (1231) Р. аның урынына кала. Иң дәрәҗәле, иң абруйлы дин әһелләренә генә бирелә торган «Мәүләнә» (төрекчә), «Мәүләви» (фарсыча) («хуҗабыз», «остазыбыз») дигән исем йөртә. Шул исемдәге Мәүләвия суфичылык тарикатен төзи. «Р.» тәхәллүсе исә Көнчыгыш Рим (Византия) империясенә кергән, Рум дип аталып йөртелгән Кече Азиягә нисбәтле кабул ителгән. Р. — 15 ел дәвамында язылган, 6 томнан торган «Мәснәви-и-мәгънәви» («Гыйбрәтле мәснәвиләр», 52 мең юл) поэмасы авторы. Әсәр фарсы халыкларының фольклор үрнәкләрен — хикәят, риваятьләрен туплаган, Коръән аятләре һәм хәдисләрнең мәгънәсен тәфсирләп аңлаткан җыентык. Шагыйрь үзенең иҗатында Илаһи хакыйкатьне танып белү юллары, җан, язмыш һәм кеше ихтыяры турында уйлана, кеше табигатенә хас кимчелекләрне тәнкыйтьли, рухи камиллеккә, төрле конфессия вәкилләрен һәм идарәчеләрне үзара татулыкка чакыра. «Көллияте Шәмс Тәбризи» исемле 60 мең шигъри юлны берләштергән газәлләр җыентыгы рухи остазы Шәмсетдин Мөхәммәткә багышланган. Эчтәлеге суфичылык тәгълиматындагыча кешене илаһилаштыру, галәмдәге һәрнәрсәне универсаль эчтәлекле Илаһият б-н кушылу дип пантеистларча аңлатудан гыйбарәт. Җыентыктагы *газәлләр* суфичылык символларына корылган, искиткеч муз. һәм экстатик кичерешләр б-н сугарылган. Р. фәлсәфи юнәлештәге чәчмә әсәрләр авторы да: «Фиһи ма фиһи» (Ибне Гарәби касыйдәсеннән алынган гыйбарә: «Аның эчендәгесе — эчендәдер»), «Мәвагыйз әл-мәҗалис әс-сәбгъ» («Җиде мәҗлес вәгазьләре»), «Мәктүбат» («Хатлар»). Р. иҗаты татар шагыйрьләре Өмми Камал, Мөхәммәдьяр, Колшәриф, Һ.Салихов, Ә.Каргалый, Ш.Зәки, Г.Тукай һ.б.ның фәлсәфи-эстетик һәм этик карашлары формалашуга йогынты ясый. «Мәснәви-и-мәгънәви» поэмасы Г.Утыз Имәни тарафыннан күчерелә һәм шәрехләнә, татар мәдрәсәләрендә фарсы теле һәм әдәбияты дәреслеге буларак хезмәт итә. Р. мирасы Г.Таһирҗанов, Ш.Абилов, Ә.Шәрипов, Х.Миңнегулов һ.б. тарафыннан өйрәнелә.

*Әд.:* Х ә к и м җ а н Ф. Мәүлана Мөхәммәт Җәләлетдин Руми (1207–1273) // Милли мәдәният. 2007. № 13; Ф и ш Р. Джалалиддин Руми. М., 1972; А к и м у ш к и н Ф.О. Вдохновенный из Рума: Поэма о скрытом смысле. М., 1986; М и н н е г у л о в Х. Целитель человеческих душ // Татарстан. 2007. № 18.

*Р.К.Ганиева.*

**РУМО́ВСКИЙ** Степан Яковлевич (29.10.1734, Владимир губ. Иске Погост а. — 6.7.1812, С.-Петербург), астроном, Петербург ФА (1767), Россия академиясе (1783) әгъзасы, Швеция ФАнең шәрәфле әгъзасы (1763). Казан уку-укыту округының беренче попечителе (1803–12). Петербург ФАнең Геогр. департаментын 30 ел җитәкли. 1748 елда М.В.Ломоносов тарафыннан Александр Невский семинариясе укучылары арасыннан сайланып алына һәм ФА каршындагы гимназиягә күчерелә. ФА каршындагы гимназиядә һәм акад. ун-тта тәрбияләнүче буларак, аны 1754 тә Берлинга укырга җибәрәләр. Анда ул математика буенча акад. Л.Эйлерда укый. 1760 та Петербургка кайта һәм акад. ун-тка математика укытырга билгеләнә; 1763 тән астрономия профессоры. 1800–03 тә Петербург ФА вице-президенты; бер үк вакытта, 1763–1803 тә, акад. обсерватория б-н җитәкчелек итә. 1803 тән Уч-щеләр баш идарәсе әгъзасы. Казан уку-укыту округы попечителе сыйфатында, Р.ның төп бурычы Казанда Россия көнчыгышының фәнни-мәгариф үзәге булырлык ун-т төзүдән гыйбарәт була. Физика-матем. ф-тын оештыручы сыйфатында ул Казан ун-тына иң яхшы профессорларны, ш.и. М.Ф.Бартельс һәм И.А.Литтровны чакыра. Венера планетасының Кояш дискы буенча узуын күзәтү өчен, Селенга (Байкал аръягы, 1761) һәм Кола ярымутравы (1769) экспедицияләрендә катнаша. Ике экспедиция нәтиҗәләре буенча Кояш параллаксының хәзергегә бик якын торучы кыйммәтен (8,67″) таба. Россиядәге 62 астрономик пунктның берләштерелгән беренче каталогын төзи (рус астрономнарының күпьеллык хезмәтләренә нигезләнеп) һәм бастырып чыгара (1786); төгәллеге буенча ул башка илләрдә басылган каталоглардан өстенрәк була. Л.Эйлерның «Төрле физик һәм фәлсәфи материяләр турында хатлар...»ын («Письма о разных физических и философских материях...», т. 1–3, СПб., 1768–74), К.Тацитның «Елъязма»сын («Летопись», т. 1–4, СПб., 1806–09), Ж.Бюфонның «Табигый тарих»ының аерым бүлекләрен («Естественная история», СПб., 1789) тәрҗемә итә. Беренче этимологик «Россия академиясе сүзлеге»н («Словарь академии Российской», ч. 1–6, СПб., 1789–94) төзүчеләрнең берсе. «Месяцелов», «Новые ежемесячные сочинения» (1786–96) астрономик календарь һәм ж-ллары мөхәррире. Петербург ФАнең Зур алтын медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сокращённая математика. СПб., 1760; Рассуждение о началах и приращении оптики. СПб., 1764; О суточном обращении Земли. СПб., 1783.

**РУМЯ́НЦЕВ** Александр Иванович (1.1.1677, башка чыганакларда 1680, Кострома өязе — 4.3.1749, Мәскәү), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, дипломат, граф (1744), генерал-аншеф (1737), сенатор (1744). Дворяннар нәселеннән. 1700 елдан хәрби һәм дәүләт хезмәтендә. 1700–21 дә — Төньяк, 1735–39 да рус-төрек сугышларында, 1711 дә Прут һәм 1722–23 тә Пётр I нең Иранга явында катнаша. 1722 ел ахыры — 1723 ел башында Казанда Каспий хәрби флотилиясе өчен суднолар төзелешенә күзәтчелек итә. 1724–26, 1740–41 дә Төркиядә илче. 1726–30 да Иранда Җир чикләү комиссиясе рәисе. 1731–35 тә, коллегияләрнең берсен җитәкләүдән баш тарту сәбәпле, Казан губернасының Алатырь провинциясе Чеборчино авылында сөргендә була. 1735–36 да Казан губернаторы. Бер үк вакытта, 1735–36 да, Башкортстан комиссиясе башлыгы. Губернада кораб төзелеше урманнарын законсыз кисү турындагы эшләрне тикшерә, башкортлардан, татарлардан гаскәр өчен атлар сатып ала. Р. вакытында Кама аръягы чик буе сызыгын төзү тәмамлана, анда 4 меңнән артык кеше урнаштырыла. «Башкорт кузгалышларын бастыру» максаты б-н тупланган хәрби частьләрнең баш командиры буларак, Оренбург экспедициясе башлыгы И.К.*Кириллов* б-н бергә Башкортстанда кузгалышларны бастыру һәм тәртип урнаштыру чараларын күрәләр (Оренбург шәһәренә нигез салына, төбәктә 20 ләп кальга-ныгытма төзелә, баш күтәрүчеләр коралсызландырыла, авылларда тимерче алачыклары ябыла, башкортларга Казан татарлары б-н туганлашу тыела, тарханнарның өстенлекләре бетерелә, җирләрне сату һәм арендага бирү, мишәр, типтәр һәм ялгызакларны тугрылыклы хезмәтләре өчен җир б-н бүләкләү тыела). 1736 ның яз-көзендә аның җитәкчелегендәге гаскәр баш күтәргән берничә отрядны тар-мар итә, Уфа провинциясендәге 100 дән артык авылны бөлгенлеккә төшерә. 1736–40 та (бүленеп) — Малороссия идарәчесе. 1742 дә Швеция б-н сөйләшүләр алып барганда рус делегациясен җитәкли, Або солых килешүенә кул куя (1743). 1744–48 дә Сенатта хезмәт итә. Изге Андрей Первозван-

ный, Изге Александр Невский орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Бантыш-Каменский Д.Н. Словарь достопамятных людей русской земли. М., 1836. Ч. 4; Лобанов-Ростовский А.Б. Русская родословная книга. СПб., 1895. Ч. 2; Петров П.Н. История родов русского дворянства. М., 1991. Кн. 2. *Е.Б.Долгов.*

**РУМЯ́НЦЕВ** Евгений Дмитриевич (4.2.1942, Тәмте р-ны Красновидово а. — 28.11.2011, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1992), проф. (1993), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994). Казан ун-тын тәмамлый (1967). 1970 елдан Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында: Ватан һәм чит илләр тарихы каф. укытучысы, 1981–86 да мәдәни-агарту эшләре ф-ты деканы, 1991–98 дә пед. һәм психол. каф. мөдире, 1999–2003 тә проректор, 2004–2011 дә Ватан һәм чит илләр тарихы кафедрасында. Хезмәтләре 20 йөз башында Идел буенда иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләр, эшчеләр сыйныфы тарихына, Татарстанда мәгариф һәм мәдәният тарихы мәсьәләләренә һәм аларның хәзерге торышына карый.

Хезм.: Рабочий класс Поволжья в годы первой мировой войны и Февральской революции. К., 1989; Долой войну, долой самодержавие! (Большевистские организации и пролетариат Поволжья в период империалистической войны и Февральской революции). Саратов. 1990; Профессиональная подготовка специалистов социокультурной среды: Прогнозирование, проектирование, практическая реализация. К., 1999 (автордаш); Социально-экономическое положение и быт рабочего класса Поволжья в годы Первой мировой войны. К., 2002.

**РУМЯ́НЦЕВ** Николай Петрович (3.4.1754, С.-Петербург — 3.1.1826, шунда ук), граф, дәүләт эшлеклесе, дипломат, сенатор (1801), Дәүләт канцлеры (1809). А.И.*Румянцевның* оныгы. 1772 елдан сарай каршында һәм дипломатик хезмәттә. 1802–10 да коммерция министры; бер үк вакытта, 1808–14 тә, тышкы эшләр министры, 1810–12 дә Дәүләт советы рәисе. Р. зур китапханә, кульъязмалар коллекциясе, этнографик һәм нумизматик материаллар туплый (Мәскәүдә Румянцев музеенда урнаштырылганнар). Россия тарихына караган хезмәт һәм документларны туплауда һәм нәшер итүдә катнаша. 1816 ның августында Казанда булып, истәлекле урыннарны зиярәт кыла һәм 1815 елгы янгын фаҗигасен кичерүчеләр файдасына акча бирә. 1817–18 дә Казан ун-тына Бразилиядә үсә торган сирәк үсемлекләр орлыклары коллекциясен бүләк итә. Казан ун-тының шәрәфле әгъзасы (1816). Изге Андрей Первозванный, Изге Александр Невский орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ивановский А.Д. Государственный канцлер граф Н.П.Румянцев: Биогр. очерк. СПб., 1871; Барсов В.В. Государственный канцлер граф Н.П.Румянцев. СПб., 1877; Иконников В.С. Граф Н.П.Румянцев: Деятельность его на пользу разработки русской истории и археологии. СПб., 1881. *Е.Б.Долгов.*

**РУМЯ́НЦЕВ** Сергей Васильевич (18.6.1913, Кострома ш. — 24.9.1990, Мәскәү), авиация двигательләре төзү өлкәсе белгече, техник фән. д-ры (1956), проф. (1956), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1968). 1937 елда Мәскәү авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Казанның 27 нче з-дында эшли. 1938 дән Казан авиация ин-тында: авиация двигательләре каф. мөдире (1938–42, 1943–44), директор урынбасары (1942–43), моторлар төзү ф-ты деканы (1944–46), авиация двигательләре теориясе каф. мөдире (1946–53), ин-тның директоры (1949–55). 1955 тән Мәскәүдә: СССР югары һәм урта махсус белем бирү министры урынбасары (1955–60), П.Лумумба исем. Халыклар дуслыгы ун-ты ректоры (1960–70), Мәскәү авиация ин-ты профессоры (1970–90). Хезмәтләре факел б-н кабызулы эчке янулы двигательләрдә эшче процессларны өйрәнүгә, турбореактив двигательле самолётларның очышын һәм күтәрелү тизлеген камилләштерүгә карый. Пешкәкле һәм реактив двигательләрдә яну процессы б-н идарә итү; очыш вакытында двигательләр б-н самолёт характеристикаларын һәм очыш программасын исәпкә алып оптималь идарә итү; авиация двигательләрен системалы проектлаштыру фәнни юнәлешләренә нигез сала. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казан технол. ун-тының бер бинасында Р.ка мемориаль такта куела.

Хезм.: Исследование факельной системы зажигания применительно к авиационным двигателям. М., 1958 (автордаш); Исследование экономичности полёта и скороподъёмности самолётов с турбореактивными двигателями. М., 1958; Системное проектирование авиационного двигателя. М., 1991.

**РУН ЯЗУЫ́**, к. *Борынгы төрки рун язуы.*

**РУНГ** Эдуард Валерьевич (7.9.1972, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (2009). Казан ун-тын тәмамлый (1994). 1998–2009 елларда Казан техник ун-тында, 2009 дан Казан ун-тының борынгы һәм урта гасырлар тарихы каф. доценты. Хезмәтләре Греция-Иран сугышлары тарихына, Грециядә дипломатик һәм дәүләтара мөнәсәбәтләрне өйрәнүгә карый.

Хезм.: Греция и Ахеменидская держава: История дипломатических отношений в VI–IV вв. до н. э. К., 2008; Греко-персидские отношения: Политика, идеология, пропаганда. К., 2009; Персидский фактор в политической жизни Греции в VI–IV вв. до н. э. К., 2012.

**РУС АКТАШЫ́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 25 *км* төньяк-көнбатыштарак, Дала Зәе елгасы буенда. 2010 елда 4235 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 77%, татарлар — 16%) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз асрау. Кирпеч з-ды, Кәләй урман сәнәгате хуҗалыгы участогы, икмәк кабул итү пункты. Урта мәктәп, коррекция интернат-мәктәбе, һөнәр уч-щесе, мәдәният йорты, 2 китапханә. Казан Богородица чиркәве (1825–30 да төзелә; архит-ра истәлеге; 1992 дән яңадан эшли). 1722 гә кадәр йомышлы татарлар авылы буларак нигезләнә. 1740 елларда җирле халык чукындырыла, Урта Идел буеның төрле төбәкләреннән тагын 49 рус крәстияне һәм татар, мордва, чуваш милләтеннән яңа чукындырылган 253 кеше күчерелә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә (бер өлеше Ижевск тимер эшкәртү з-дына беркетелә), игенчелек, терлекчелек, умартачылык, олаучылык, сәүдә, балта эше, күн аяк киеме тегү, мичкә ясау, тимерчелек, йон тетү, такта яру һ.б. кәсепләр б-н көн итә. 1841 дә Р.А.нда (икенче исеме — Богородский) чиркәү, кабак, тимерче алачыгы, 4 су тегермәне эшли. 1900 елгы мәгълүматларга караганда, волость идарәсе урнаша; чиркәү, ир һәм кыз балалар земство мәктәпләре (1876 да ачылалар), земство аптекасы, 4 су тегермәне, 3 икмәк саклау-сату кибете, 4 май язу з-ды, 3 тимерче алачыгы, 10 вак-төякләр һәм шәраб кибете, 2 сыраханә була; җомга базары, 8 июль һәм 22 октябрь көннәрендә ярминкә эшли. 1912 дә Халык мәгарифе министрлыгының 2 класслы уч-щесе, амбулатория пункты, кредит ширкәте ачыла. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 7687,1 дис. тәшкил итә. Гражданнар сугышы чорында Р.А. 1920 елгы *«Сәнәкчеләр» фетнәсе* вакыйгаларының үзәгендә була. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Акташ волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ р-ны үзәге, 1957 нең 28 сентябрендә шәһәр тибындагы посёлок статусын ала, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында, 2004 нең 25 октябреннән — авыл. Халык саны: 1782 дә — 459 ир-ат; 1795 тә — 964, 1841 дә — 1602, 1870 тә — 1828, 1884 тә — 3114, 1897 дә — 3350, 1912 дә — 3974, 1920 дә — 3711, 1926 да — 3316, 1938 дә — 3262, 1949 да — 2826, 1958 дә — 1192, 1970 тә — 1302, 1979 да — 1125, 1989 да — 3300, 2002 дә — 4187 кеше.

**РУС АЛАТЫ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 33 *км* төньяктарак, Ашыт елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 206 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорында (*Алат даругасы* үзәге була) нигез салына. 1558 дән руслар урнаша башлый. 1708 дән — Казан губернасы шәһәре, 1766 дан — дәүләт крәстияннәреннән торган авыл. 18 йөздә Р.А.нда бакыр кою, күн эшкәртү, аракы з-длары эшли. 19 йөздә халкы игенчелек, терлек асрау, кирпеч сугу, чүлмәк ясау, тегүчелек, итек тегү, балта эше һ.б. кәсепләр б-н көн итә. 1712 дә Успение чиркәве (архит-ра истәлеге) төзелә. 1773 нең июнендә Р.А.нда берничә көн бу як кешесе Дружинин б-н Казан төрмәсеннән качкан Е.И.Пугачёв була. Авылда Казан сәүдәгәре һәм эшмәкәре И.А.*Михляев* туган. 1861 дә Р.А.нда укырга-язарга өйрәтү мәктәбе ачыла, 1867 дән ул Халык мәгарифе министрлыгы карамагында була. 1897 дән — участок табибе эшли, 1900 дән — земство хастаханәсе, 1907 дән телефон станциясе ачыла. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; 4 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, тимерче остаханәсе, йон-тукыма ману йорты, 1 казна шәраб һәм 6 вак-төякләр кибете, 3 сыраханә, ашханә, 3 чәйханә була; дүшәмбе базары эшли. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Алат волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык

саны: 1646 да — 223, 1767 дә — 215 ир-ат; 1859 да — 545, 1897 дә — 712, 1920 дә — 741, 1926 да — 839, 1938 дә — 746, 1949 да — 686, 1958 дә — 454, 1970 тә — 266, 1989 да — 210, 2002 дә — 189 кеше.

*Әд.:* Описание уездных городов и замечательных селений Казанской губернии. К., 1862; Известия по Казанской епархии. К., 1880; Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885; Историко-статистическое описание церквей и приходов Казанского уезда. К., 1916; Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**РУС АЛЫНМАЛАРЫ́**, рус теленнән кергән сүзләр. Дөньядагы барлык телләрдә, аеруча РФдә һәм ССРның элеккеге союздаш респ-каларында яшәүче халыкларның телләрендә еш очрый. Татар телендә дә Р.а. шактый; бу руслар б-н татарларның үзара тыгыз аралашып яшәүләренә, хуҗалык, мәдәният бәйләнешләренә бәйле. Казан ханлыгы Рус дәүләте тарафыннан яулап алынганга кадәр үк инде руслардан арыш, буразна, бүрәнә, дуга, күчтәнәч, матча, өстәл, салам, уҗым кебек сүзләр кергән була. 16 йөз уртасыннан башлап, татар теленә телдән телгә күчеп яки язма рәвештә төрле фонетик үзгәрешләргә дучар ителгән хәлдә русча адм. терминнар (өяз, указ, пошлина), вазифа һәм катлау атамалары (воевода, десятник, староста), көнкүреш-хуҗалык лексикасы (дегет, мунчала, чират) һ.б. керә. 19 йөз ахырыннан Р.а. татар теленә, кагыйдә буларак, үзгәрешсез керә башлый (союз, съезд, самолёт, училище, колхоз). Рус теле аша икътисад һәм финанс (бартер, бизнес, инвестор), иҗтимагый-сәяси тормыш (лобби, рейтинг, саммит), фән һәм техника (Интернет, ноу-хау, нанотехнология), мәдәният һәм сәнгать (диджей, видеоклип, продюсер), физкультура һәм спорт (аэробика, ралли, шейпинг), көнкүреш (гамбургер, евроремонт) һ.б. өлкәләргә караган төшенчәләрне белдергән *интернациональ сүзләр* дә күпләп керә (20 йөз ахырында — 21 йөз башында *алынмаларның* төп өлешен тәшкил итәләр). Совет чорының соңгы елларында һәм совет чорыннан соңгы дәвердә рус теленнән күбрәк *гади сөйләм* сүзләре (братва, ломка, челнок) яки *аббревиатуралар* (ГЭС, ТЭЦ, КБ, бомж) күчә башлый. Бер үк вакытта төрки-татар сүзләренең дә рус теленә керүе дәвам итә: дорога, товарищ, лошадь, карандаш һ.б. Татар телендә рус алынмаларын өйрәнү-тикшерү б-н Ә.М.Ахунҗанов шөгыльләнә.

*Әд.:* Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. К., 1999; Мөхиярова Р.Х. XX гасырның 80–90 нчы елларында татар әдәби теле лексикасы. Яр Чаллы, 2000; Ахунзянов Э.М. Русские заимствования в татарском языке. К., 1968; Абдуллин И.А., Ахунзянов Г.Х., Ганиев Ф.А. Русский язык — один из источников обогащения и развития татарского литературного языка // Взаимодействие и взаимообогащение языков народов СССР. М., 1969.

*Р.Ә.Закиров.*

**РУС ӘДӘБИЯТЫ́Н СӨЮЧЕЛӘ́Р ҖӘМГЫЯТЕ́**, Казан Император университеты каршында. А.С.Пушкин истәлегенә Казанда 1899 елда А.С.*Архангельский* һәм Е.Ф.*Будде* башлангычы б-н төзелә. Җәмгыятьнең максаты — «рус һәм башка славян халыкларының тел тарихы, әдәбият һәм халык иҗаты мәсьәләләрен төрле яклап өйрәнү, ш.у. алда әйтелгән мәсьәләләр буенча мәгълүматларны рус җәмгыятендә тарату һәм шуңа карата кызыксыну уяту». Җәмгыять әгъзалары һәм иганәчеләр акчасы хисабына яши. Җәмгыять әгъзалары арасында — А.И.Александров, Е.А.Бобров, А.И.Смирнов, Н.П.Загоскин, И.Н.Смирнов, Н.Ф.Катанов, С.П. һәм Д.П.Шестаковлар, Д.И.Дубяго һ.б., шәрәфле әгъзалар В.Ф.Миллер, А.Н.Пыпин, П.Д.Боборыкин. 1907 гә кадәр җәмгыятьнең рәисе А.С.Архангельский була. Ул С.-Петербургка киткәннән соң, җәмгыятьнең исеме генә яши. 1916 да аның эшчәнлеге тергезелә һәм 1918 гә кадәр дәвам итә (рәисе — Н.М.Петровский). 1921 дә, ун-тның «иске хакимиятнең идеологик таянычы», «консерватизм таратучы» дип саналган тарих-филол. ф-ты ябылу уңаеннан, җәмгыять эшчәнлеге туктатыла.

*Әд.:* Воронова Л.Я. Литературное общество при Казанском университете в конце XIX — начале XX в. // Лингвистические и эстетические аспекты анализа текста и речи: Сб. статей Всерос. науч. конф. Соликамск, 2002. Т. 3.

*Л.Я.Воронова.*

**РУС ӘДӘБИЯТЫ́Н СӨЮЧЕЛӘРНЕ́Ң КАЗА́Н ҖӘМГЫЯТЕ́**, Казан, Идел һәм Урал буе рус язучыларының беренче әдәби-фәнни оешмасы. Казанда 1806 елда Беренче ир балалар гимназиясе каршында оеша (соңыннан Казан. ун-ты каршында эшли). Җәмгыять төзүдә башлап йөрүче һәм беренче рәисе — Н.М.*Ибраһимов.* Җәмгыятьнең максаты — «язучыларның үзләрен әдәбиятта камилләштерү теләге», «ватан әдәбиятының уңышларын таратуга» ярдәм итү. 1806–14 елларда җәмгыятьнең хакыйкый әгъзалары — П.С.Кондырев (алыштыргысыз секретарь), В.М.Перевощиков, К.Ф.Фукс, С.А.Москотильников, Г.И.Солнцев, В.И.Панаев, И.М.Симонов, Я.О.Ярцев, С.Т.Аксаков, Н.С.Арцыбашев, Ф.М.Рындовский, А.И.Тургенев, шәрәфле әгъзалары — К.Н.Батюшков, Г.Р.Державин, В.А.Жуковский, Н.М.Карамзин, В.В.Капнист һ.б. Җәмгыятьнең Программасы һәм 1814 тә расланган Уставы була. 1818 дә җәмгыятьтә 100 кеше исәпләнә, ш.и. 25 е — читтә яшәүчеләр. Ачык җыелышлар уздырыла. Г.Р.Державин истәлегенә багышланган җыелышта (1816) җәмгыять әгъзалары Казанда шагыйрьгә һәйкәл кую тәкъдиме б-н чыгыш ясыйлар. 1817 дә «Рус әдәбиятын сөючеләрнең Казан җәмгыяте хезмәтләре»нең 1 нче китабы дөнья күрә. Казанның уку-укыту округы җитәкчесе М.Л.Магницкий вакытында (1819–26) җәмгыять үзенең эшчәнлеген вакытлыча туктата, 1828 дә генә кабат дәвам итә. 1830 дан соң җәмгыятьнең җыелышлары сирәгәя, соңрак бөтенләй туктатыла. 1846 да ул яңадан тергезелә, ләкин эшчәнлегенең эчтәлеге һәм характеры нык үзгәрә: утырышлар тематикасы әдәби юнәлешен югалта, алар төрле фәннәргә һәм башка өлкәләргә багышлана. Җәмгыятьнең составы күбрәк университет профессорлары — төрле фәнни юнәлеш вәкилләре хисабына тулылана. Соңгы утырыш 1853 нең 24 сентябрендә уза. Казан җәмгыяте төбәкнең әдәби һәм рухи тормышын үстерүдә сизелерлек роль уйный, зыялыларны агарту эшчәнлегенә тартуга сәбәпче була, Петербург һәм Мәскәү җәмәгатьчелеге тарафыннан да таныла.

*Әд.:* Загоскин Н.П. История Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1903. Т. 2; Литвина Ф.А. Литературно-общественная жизнь Казани в конце XVIII — первой половины XIX вв. // Страницы истории города Казани. К., 1981; Аристов В.В. Первое литературное общество Поволжья. К., 1992.

*В.И.Шишкин.*

**РУС ӘҖИЛЕ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 46 *км* төньяк-көнбатыштарак, Гөбенә елгасы буенда. 2010 елда 73 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 53%, руслар — 45%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Р.Ә.ндә волость идарәсе урнаша; Тихвин Богородица чиркәве, земство мәктәбе (1869 да ачыла), 1 җил һәм 1 су тегермәне, 2 тимерче остаханәсе, ярма яргыч, 1 казна шәраб һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 450,21 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 41 ир-ат; 1859 да — 289, 1897 дә — 457, 1908 дә — 575, 1920 дә — 521, 1926 да — 537, 1938 дә — 599, 1949 да — 245, 1958 дә — 169, 1970 тә — 170, 1979 да — 157, 1989 да — 126, 2002 дә — 131 кеше.

**РУС ӘМЗӘСЕ́** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 59 *км* төньяк-көнбатыштарак, Гәрәй елгасы буенда. 2010 елда 42 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөз башында нигез салына. 1920 елларга кадәрге рәсми чыганакларда Р.Ә. составында Иске Әмзә авылы да була. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында тимерче остаханәсе, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1655 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Әлмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 53 ир-ат; 1859 да — 1010, 1897 дә — 1658, 1908 дә — 2031, 1920 дә — 1832, 1926 да — 474, 1938 дә — 260, 1949 да — 226, 1958 дә — 151, 1970 тә — 95, 1979 да — 69, 1989 да — 47, 2002 дә — 31 кеше.

**РУС ӘШНӘГЕ́** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 10 *км* көнбатыштарак, Әшнәк елгасы буенда. 2010 елда 410 кеше (2002 ел-

гы халык исәбе буенча, руслар — 55%, татарлар — 44%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1617 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Әшнәк, Троицкий исемнәре б-н дә билгеле. Халкы башта сарай ведомствосына, 1797–1860 елларда удел крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, он тарту, балта эше, тимерчелек һәм тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Троица чиркәве (1791 дә төзелә), земство мәктәбе (1867 дә ачыла), 1 су һәм 2 җил тегермәне, 2 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 5 вак-төякләр кибете, Халыкта аек яшәү рәвеше тәрбияләүче попечительлек өяз ком-ты уку өе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3087,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Анатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 409 ир-ат; 1859 да — 1476, 1897 дә — 2010, 1908 дә — 2345, 1920 дә — 2211, 1926 да — 2083, 1949 да — 1136, 1958 дә — 820, 1970 тә — 625, 1989 да — 474, 2002 дә — 528 кеше.

**РУС БӘРЛЕБАШЫ́** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 7 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бәрле елгасы буенда. 2010 елда 208 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 53%, руслар — 47%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, чөгендер үстерү. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөз башында нигез салына. 18 йөз ахыры чыганакларында — Багыш, 19 йөздә — 20 йөзнең 1 нче яртысында Рус Бәрлебашы буларак билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чүлмәк ясау, тәгәрмәч ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Р.Б.нда Никольский чиркәве, земство мәктәбе, чүлмәкче остаханәсе, 6 кибет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1213 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Кошман волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 110 ир-ат; 1859 да — 582, 1897 дә — 1262, 1908 дә — 1487, 1920 дә — 1334, 1926 да — 1196, 1948 дә — 794, 1958 дә — 657, 1979 да — 426, 1989 да — 285 кеше.

**РУС БОГДА́ШКИНОСЫ** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 22 *км* төньяктарак, Киекле елгасы буенда. 2010 елда 572 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 72%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1700 еллар тирәсендә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Р.Б.нда чиркәү, сыраханә, 1 шәраб һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2306 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Чаллы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 113 ир-ат; 1859 да — 905, 1897 дә — 1366, 1908 дә — 1612, 1920 дә — 1872, 1926 да — 1924, 1938 дә — 1332, 1949 да — 1003, 1958 дә — 898, 1970 тә — 1180, 1979 да — 810, 1989 да — 585, 2002 дә — 608 кеше.

**РУС БОРНАШЫ́** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 27 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 179 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. Клуб, китапханә. 1565–67 еллардан мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Р.Б.нда Христово Рождество чиркәве, земство мәктәбе (1884 тә ачыла), 6 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2382 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Юмат волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 249 ир-ат; 1859 да — 804, 1908 дә — 1464, 1920 дә — 1313, 1926 да — 1332, 1938 дә — 969, 1949 да — 566, 1958 дә — 482, 1970 тә — 352, 1979 да — 286, 1989 да — 206, 2002 дә — 177 кеше.

**РУС БОРТАСЫ́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 34 *км* төньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 110 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Р.Б. ике авыл — Югары Бортас һәм Түбән Бортас буларак билгеле. 1695 кә кадәр ике авыл да Казан архиерей йортыныкы, соңрак дворян Савельевлар варисларыныкы булып исәпләнә. Җирле халык, игенчелек һәм терлекчелектән тыш, бакчачылык, агач эшкәртү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Р.Б.нда Христово Рождество чиркәве (1761 дә төзелә), земство мәктәбе (1885 тә ачыла), тимерче остаханәсе, 1 су һәм 5 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда 2 авылның берләштерелгән имана җире 1008 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Тәмте волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Кама Тамагы, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 273 ир-ат; 1859 да — 773, 1897 дә — 866, 1908 дә — 972, 1926 да — 895, 1938 дә — 846, 1949 да — 553, 1958 дә — 536, 1970 тә — 419, 1979 да — 340, 1989 да — 231, 2002 дә — 191 кеше.

**РУС ГАСКӘРИЛӘРЕ́ ҺӘЙКӘ́Л-ТӨРБӘСЕ́**, Казанны яулаганда һәлак булганнарга куелган храм-төрбә; архит-ра истәлеге. 1813–23 елларда Успение Елантау монастыре башлыгы Амвросий (Сретенский) башлангычында монастырь халкы җыйган акчага, император Александр I карары нигезендә кәшәнә һәм 1552 дә Казанны яулап алганда һәлак булган рус сугышчыларының туганнар каберлеге урынында Петербург архитекторы Н.Ф.Алфёров проекты буенча төзелә. Төзелеш б-н арх. М.Е.*Емельянов* җитәкчелек итә. 1830–32 дә храм-һәйкәл арх. П.Г.*Пятницкий* проекты буенча реконструкцияләнә: гөмбәзләре һәм ярымшары яңадан корыла, яр буйлары ныгытыла, көнчыгыш якка баскыч урнаштырыла. 1830 да һәйкәл Казан сәүдәгәрләр җыены карамагына тапшырыла, 1870 тән шәһәр үзидарәсе оешмаларына бирелә (храм чиркәве Успение Елантау монастырена беркетелә). 1834 тә һәйкәл әйләнәсе тимер чылбырлы таш баганалар б-н корып алына; 1837 дә пирамиданың диварлары табаклы калай б-н ябыла, кара төскә буяла, портиклары агартыла.



Казанны яулаганда һәлак булган рус гаскәриләре һәйкәл-төрбәсе. 1823. Архитекторы Н.Ф.Алфёров. 2008 елгы фоторәсем.

Бина планда эчке гөмбәзле, яклары 20 *м* лы квадратка утыртылган кисек пирамида рәвешендәге корылма тәшкил итә. Дүрт фасадның һәр ягында бинага керү урыннары булган ике колонналы дорик портиклар төзелгән; һәр портикка киң баскыч тоташтырылган. Бинада искә алу тантаналары үткәрү чиркәве урнашкан. Төрбәгә көньяк портиктан гөмбәзсыман җир асты куышы аша таш баскыч алып бара. Пирамида почмакларына хөҗрәләр корып куелган. Мемориаль чиркәү интерьеры (сакланмаган) ампир стилендә төзелгән; портикларның фронтоннары тасмалы такыялар, эчке диварлары сөңгеләр һәм кечкенә балталар бәйләме б-н бизәлгән. 1836 ның августында һәйкәл-төрбәдә император Николай I, 1839 ның июлендә аның улы тәхет варисы Александр була. 1918 дә храмда дини йолалар башкару туктатыла.

Баштарак һәйкәл Казансу елгасының иске агымындагы биек сул як ярында тора. 1958 дә Идел суның биеклеге күтәртелгәннән һәм Казан тирәли саклау дамбалары төзелгәннән соң, ул кечкенә утрауда, су басу зонасында кала. 2005 тә чиркәү карамагына тапшырыла, приход храмы буларак файдаланыла.

*Әд.:* Гавриил (Воскресенский). Историческое описание Казанского Успенского второклассного

Зилантова монастыря и Казанского памятника... К., 1840; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Республика Татарстан: Православные памятники (середина XVI — начало XX веков). К., 1998; Православные храмы Татарстана: Альбом. К., 2000.

*Х.Г.Надыйрова, Е.В.Липаков.*

**РУС ИСЛАМЫ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 34 *км* көньяк-көнбатыштарак, Әрә елгасы буенда. 2010 елда 2 кеше (руслар) яши. 1646 дан Ислам авылы буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысыннан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Р.И.нда мөселман гыйбадәтханәсе, 3 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 664 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 90 ир-ат; 1859 да — 433, 1897 дә — 704, 1908 дә — 735, 1920 дә — 853 (Татар Исламы авылын да кертеп), 1926 да — 766, 1938 дә — 444, 1949 да — 229, 1958 дә — 105, 1970 тә — 40, 1979 да — 25, 1989 да — 6, 2002 дә — 4 кеше.

**РУС КАРАНЫ́** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 23 *км* көньяктарак, Ык елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 87 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1731 елга кадәр нигез салына. Беренче исеме — Зур Каряк (башкалары — Зур Коряк, Зур Карин). Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Каран исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, су һәм җил тегермәне, икмәк саклау-сату кибете, 5 бакалея кибете була. 20 йөз башында земство мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2911 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Богодаровка волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 198, 1858 дә — 567, 1870 тә — 773, 1884 тә — 792, 1897 дә — 1039, 1908 дә — 1163, 1913 тә — 1185, 1920 дә — 1025, 1926 да — 934, 1938 дә — 543, 1949 да — 406, 1958 дә — 363, 1970 тә — 314, 1979 да — 216, 1989 да — 119, 2002 дә — 96 кеше.

*Әд.:* Мензелинский край: История и современность. Мензелинск, 2006.

**РУС КАРМӘТЕ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 8 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кармәт елгасы буенда. 2010 елда 338 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 68%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. Р.К. 1964 нең 23 апрелендә Иске Рус Кармәте (17 йөз ахырында — 18 йөз башында нигезләнә) һәм Дмитриевка (Дмитриевский; 18 йөз ахырында нигезләнә) авыллары кушылу нәтиҗәсендә барлыкка килә. 1861 елгы реформага кадәр ике авыл халкы да алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Дмитриевка авылында Казан Богородица чиркәве (1887 дә төзелә; архит-ра истәлеге; 1990 еллардан яңадан эшли башлый), земство мәктәбе (1868 дә ачыла), пар һәм су тегермәннәре, ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете; Иске Рус Кармәтендә 4 җил тегермәне, 2 тимерче алачыгы, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире Дмитриевкада — 890, Иске Рус Кармәтендә 456 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Аксубай волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә Иске Рус Кармәтендә (1970 тән — Рус Кармәте) — 87 ир-ат; 1859 да — 554 (Дмитриевкада — 529), 1897 дә — 638 (495), 1908 дә — 699 (564), 1920 дә — 806 (699), 1926 да — 667 (472), 1938 дә — 766, 1949 да — 446, 1958 дә — 438, 1970 тә — 973, 1979 да — 764, 1989 да — 444, 2002 дә — 365 кеше.

**РУС КИРМӘНЕ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 18 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 23 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1680 елларга кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 19 йөздә Р.К. янында бакыр эретү з-ды эшли. 20 йөз башында Петропавел чиркәве, земство мәктәбе (1868 дә ачыла), 2 су тегермәне, тимерче алачыгы, 1 казна шәраб һәм 6 вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2573 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кирмән волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 183 ир-ат; 1859 да — 1225, 1897 дә — 1592, 1908 дә — 1757, 1920 дә — 1613, 1926 да — 1729, 1938 дә — 750, 1949 да — 424, 1958 дә — 317, 1970 тә — 192, 1979 да — 102, 1989 да — 50, 2002 дә — 33 кеше.

**РУС КИШТӘГЕ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Зөя елгасыннан 1,5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 170 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 61%, чуашлар — 36%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1646–52 дә Кищага исеме б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү, земство мәктәбе, 4 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 637 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 433, 1897 дә — 611, 1913 тә — 590, 1920 дә — 731, 1926 да — 784, 1938 дә — 795, 1949 да — 272, 1958 дә — 235, 1970 тә — 300, 1979 да — 259, 1989 да — 190, 2002 дә — 243 кеше.

**РУС КЫРЫ́К САДАГЫ́** авылы, Буа р-нында, Буа р-ныннан 31 *км* көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш. 2010 елда 102 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Никольский, Михайловка, Кырык Садак исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 318,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Тимбай волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 342, 1897 дә — 329, 1913 тә — 473, 1920 дә — 445, 1926 да — 465, 1938 дә — 539, 1949 да — 215, 1958 дә — 344, 1970 тә — 241, 1979 да — 234, 1989 да — 159, 2002 дә — 105 кеше.

**РУС МАКЫЛЫ́** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 1234 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 66%, татарлар — 31%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; а.х. техникасы пр-тиесе, сөт з-ды. Урта мәктәп, һөнәр уч-щесе, мәдәният йорты, китапханә, хастаханә. 1646 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Макулово исеме б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тәгәрмәч, чана табаны һәм тугымы, агач савыт-саба ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Богоявление чиркәве (1849 да төзелә), земство мәктәбе (1880 нәрдә ачыла), телефон, 3 җил тегермәне, тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1401 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Келәнче волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 156 ир-ат; 1859 да — 625, 1897 дә — 943, 1908 дә — 978, 1920 дә — 970, 1926 да — 884, 1938 дә — 595, 1949 да — 434, 1958 дә — 360, 1970 тә — 287, 1979 да — 581, 1989 да — 1140, 2002 дә — 1173 кеше.

**РУС МӘНҖЕСЕ́** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Чирмешән елгасы буенда. 2010 ел-

да 148 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 64%, руслар — 34%) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. 1794 тән рус чыганакларында — Менча Зубова, 1860 еллардан Менча буларак билгеле; 1880 еллардан хәзерге исемен йөртә. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (граф А.Н.Зубов нәселенеке булып санала) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Р.М.ндә чиркәү (1868 дә төзелә, 1929 да ябыла), чиркәү-приход мәктәбе (1885 тә ачыла), 2 су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 997 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Егоркино волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1859 да — 350, 1897 дә — 583, 1908 дә — 669, 1920 дә — 737, 1926 да — 695, 1938 дә — 628, 1949 да — 452, 1958 дә — 455, 1970 тә — 235, 1979 да — 147, 1989 да — 1276, 2002 дә — 159 кеше.

**РУС МОРАСАСЫ́**, к. *Мораса*.

**РУС МӨШЕГЕСЕ́** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 38 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мөшеге елгасы буенда. 2010 елда 59 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1709 дан мари авылы буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Мөшеге, Керәшен Мөшегесе исемнәре б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе, икмәк саклау-сату һәм бакалея кибете, 3 тегермән, 1 кабак була; дүшәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 866 дис. тәшкил итә. 1919 га кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы (1919–20 дә Әтрәкле) волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1858 дә — 260, 1884 тә — 399, 1906 да — 394, 1913 тә — 547, 1920 дә — 508, 1926 да — 496, 1938 дә — 359, 1949 да — 219, 1958 дә — 181, 1970 тә — 142, 1979 да — 85, 1989 да — 66, 2002 дә — 70 кеше.

*Әд.:* Мензелинский край: История и современность. Мензелинск, 2006.

**РУС МУ́ЗЫКА ҖӘМГЫЯТЕНЕ́Ң КАЗА́Н БҮЛЕГЕ́**, Рус музыка җәмгыятенең (РМҖ, 1869 елдан — Император РМҖ) беренче җирле бүлекләреннән (С.-Петербург, Мәскәү һәм Киевтан кала) берсе. 1864 тә ачыла. Җәмгыятьнең максаты устав нигезендә Россиядә музыка белемен җәелдерүгә, сәнгатьнең барлык өлкәләрен үстерүгә булышлык итү, илнең сәләтле иҗатчылары (көй язучылар һәм башкаручылар) һәм музыка фәннәре укытучыларының хезмәтләрен бәяләү дип билгеләнә. Белем бирү һәм концерт оешмаларының тыгыз элемтәсе идеясе җәмгыять яшәү дәверендә гамәлгә ашырыла. Ул концертлар оештыра, аның кысаларында музыка уку йортлары төзелә (аларның директорлары җәмгыятьнең Баш дирекциясе составына керә).

Бүлекне дирекция җитәкли (Петербургтагы Баш дирекция тарафыннан билгеләнә), ул бүлекнең «барлык музыка, сәнгать, оештыру эшләре» б-н идарә итә.

Р.м.җ.К.б.нең актив эшчәнлеге таркалу һәм торгынлык еллары б-н чиратлаша. 1887–92 дә Казанның музыкаль тормышында җәмгыять шактый зур роль уйный, бу чорда аның эшен танылган музыка эшлеклесе, комп. һәм дирижёр А.Орлов-Соколовский җайга салып җибәрә. Аннан тыш дирекция составына дворяннар башлыгы С.Теренин (дирекция рәисе), Казан музыкантлары П.Александров, С.Гилев керәләр. Бу елларда даими рәвештә симф. һәм камера концертлары оештырыла, еш кына квартет кичәләре уздырыла. Концертларда төп башкаручылар А.Орлов-Соколовскийның Җәмәгать музыка мәктәбе укытучылары була. Ул Казаннан киткәч, җәмгыятьнең эшчәнлеге, 19 йөз ахырында бөтенләй туктаганчы, акрынлап сүнә. Аны тергезү эшләре Р.А.*Гуммерт* тырышлыгы б-н башкарыла, 1900 нең 24 июнендә ул Казан губернаторы исеменә шәһәрдә РМҖ бүлеген ачу турында гариза бирә, һәм 1902 нең 26 маенда бүлек кабаттан ачыла. Р.м.җ.К.б., Казанда музыкаль тормышны үстерүнең төп процессларын җайга салып, шәһәргә Россиянең иң зур губерна музыка үзәкләренең берсе дигән танылу китерә. Бу чорда бүлек дирекциясен Н.Сазонов, А.Боратынский, И.Кривоносов, С.Бечко-Друзин җитәкли. Җәмгыять җитәкчелеге эшенә дворяннардан, сәүдәгәрләр катлавыннан, фәнни даирәләрдән, сәнәгать эшлеклеләреннән Л.Кекин, М.Кремков, А.Ушков, И.Брюно, Д.Персон, Э.Грахе, Ф.Амлонг, Я.Молотков һ.б. музыка сөючеләр керә. Җәмгыять эшендә Р.м.җ.К.б. рәисе, музыка уч-щесе директоры Р.Гуммертның роле аеруча зур була. 1910 нан Император РМҖ Баш дирекциясенең Казан бүлегендә Казан губернасында туган атаклы рус җырчысы Н.Фигнер рәислек итә.

Җәмгыять эшенең мөһим юнәлеше булып концерт эшчәнлеге санала, бүлек филармония оешмасы функцияләрен башкара. Җәмгыять Казанда мәшһүр музыкантлар С.Рахманинов, А.Скрябин, Л.Собинов, А.Нежданова, С.Танеев, К.Игумнов, А.Гольденвейзер, Л.Ауэр, И.Гофман, С.Танеев, Я.Кубелик, В.Ландовская, А.Рубинштейн гастрольләрен башлап җибәрүче була. Концертларда Казан музыкантлары, башлыча, Казан музыка уч-щесе укытучылары Р.Гуммерт, О.Родзевич, М.Пятницкая, Е.Янишевская, А.Ратнер; скрипкачылар А.Амиго, К.Скибицкий; виолончельче Н.Грюнберг; җырчылар Е.Ковелькова, М.Михайлов һ.б. һәрдаим чыгыш ясыйлар. Музыка укытучылары көче б-н җәмгыятьнең Казан бүлеге кыллы квартеты оеша, һәм ул актив концерт эшчәнлеге алып бара.

Казан мәдәни тормышының әһәмиятле өлеше булып Р.м.җ.К.б. үткәргән симф. концертлар тора. Оркестр коллективы театр оркестры музыкантларыннан, музыка уч-щесе педагогларыннан туплана. Бу иҗтимагый симф. концертларда дирижёр буларак Р.Гуммерт, А.Амиго, башкала дирижёрлары Н.Клеановский, Э.Купер, А.Хессин һәрдаим чыгыш ясыйлар. 1912 һәм 1914 тә Р.м.җ.К.б. Казанда танылган рус дирижёры һәм музыка эшлеклесе С.Кусевицкийның симф. оркестры гастрольләрен оештыру эшендә башлап йөри. Концерт репертуары чит ил һәм рус классик музыкасыннан төзелә, шул чор композиторларының әсәрләрен пропагандалый.

Р.м.җ.К.б.нең әһәмиятле юнәлеше музыка белеме бирү мәктәпләрен оештыру була. 1904 тән бүлек каршында кыска вакыт эчендә Идел буеның иң зур музыка белеме үзәкләренең берсенә әверелгән Казан музыка уч-щесе (Р.Гуммертның музыка мәктәбе нигезендә) ачыла. 1912 дә Петербургта РМҖнең музыка уку йортлары директорлары съездында ул Россиядәге иң яхшы дүрт уч-щенең (Киев, Харьков һәм Одесса б-н беррәттән) берсе итеп күрсәтелә. Бүлек Идел-Кама төбәгендә музыка белемен таратуны оештыра. Дирекция ярдәме һәм аның рәисе И.Кривоносовның турыдан-туры катнашы б-н 1909 да җәмгыятьнең Казан бүлеге каршында Вятка губернасы шәһәрләрендә, Сарапул һәм Алабугада музыка класслары, ш.у. Казанда Түләүсез регентлык (1905–15) һәм оркестр (1905–11) класслары ачыла. Оркестр Халыкта аек яшәү рәвеше тәрбияләүче попечительлек ком-тының матди ярдәме б-н оештырыла. Октябрь рев-циясеннән соң РМҖ һәм аның Казан бүлеге үзенең эшчәнлеген туктата.

*Е.В.Порфирьева.*

**РУС НАРАТЛЫСЫ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 42 *км* көньяктарак, Гөбенә елгасы буенда. 2010 елда 19 кеше (руслар) яши. 1646–52 дән рус чыганакларында — Норатлеива, рев-циягә кадәрге чыганакларда Рус Наратлеи исемнәре б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне, ярма яргыч, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 256 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 39 ир-ат; 1859 да — 169, 1897 дә — 276, 1908 дә — 348, 1920 дә — 356, 1926 да — 401, 1938 дә — 375, 1949 да — 155, 1958 дә — 127, 1970 тә — 87, 1979 да — 42, 1989 да — 22, 2002 дә — 14 кеше.

**РУС ПАКШИНЫ́** посёлогы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 15 *км* көньяк-көнбатыштарак, Пакшин елгасы буенда. 2010 елда 77 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 19 йөзнең 1 нче чирегендә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Р.П.нда су тегермәне була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 356 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының

Мамадыш өязе Троицк-Сәкинәс волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 127, 1897 дә — 187, 1908 дә — 217, 1920 дә — 207, 1926 да — 226, 1938 дә — 188, 1949 да — 132, 1958 дә — 86, 1970 тә — 92, 1979 да — 86, 1989 да — 80, 2002 дә — 82 кеше.

**«РУС ПАТШÁ-ХАЛЫ́К ҖӘМГЫЯТÉ»**, К а з а н д а, 1905 елның декабреннән 1917 нең мартына кадәр Казан губернасында эшчәнлек алып барган уң монархиячел (карагруһчыл) иҗтимагый-сәяси оешма. 1905 нең 4 декабрендә Казан халкы һәм Казанда йорт тотучылар берләшкән төркемнең 3 нче җыены тарафыннан гамәлгә куела. 1905 нең 11 декабрендә җәмгыять Казан губернаторы вазифасын башкаручы А.А.Рейнботка революцион пропагандага чик куюда хөкүмәткә актив булышлык күрсәтү тәкъдиме б-н мөрәҗәгать итә. Җәмгыять эшчәнлеген 1 нче составына 9 кеше, ш.и. проф. В.Ф.Залесский (рәис), С.А.Соколовский (секретарь), А.Е.Дубровский, А.В.Калягин, П.Ф.Мойкин, И.Л.Панфилов, рухани Н.М.Троицкий кергән Совет җитәкли. Казан губернаторы М.В.Стрижевский, Уфа губернаторы А.С.Ключарёв, Казан вице-губернаторы Д.Д.Кобеко, епископ Алексий (А.Я.Дородницын), кенәз А.Г.Щербатов һ.б. «Р.п.-х.ж.»нә шәрәфле әгъза буларак кабул ителәләр. Оешма төрле катлау вәкилләрен берләштерә, киң таралыш ала. 1906 ның 4 ноябрендә расланган Устав буенча «Р.п.-х.ж.»нең төп максатлары дип «православие, самодержавие һәм халыкчанлыкның чын рус башлангычларын саклау юлы аркылы» үз карашларының теоретик нигезләрен эшләү һәм аларны тормышка ашыру, ш.у. тыныч чаралар б-н «парламентаризмның зарарлы йогынтысына» каршы көрәшү билгеләнә. Оешманың сәяси активлыгы 1906–07 дә, әгъзаларының саны («теркәлмәгәннәр» һәм теләктәшләрне дә кертеп), төрле мәгълүматларга караганда, 1,5 тән 15 меңгә кадәр кеше тәшкил иткән чорда, иң югары ноктасына җитә. Җәмгыять җыеннары, гадәттә, иркен биналарда (башлыча, Казан пехота юнкерлар уч-щесе манежында) уза. 1906 ның ноябрендә «Р.п.-х.ж.» рәисе Залесский бер үк вакытта *«Рус халкы берлеге»нең* Казан губерна бүлеге Советын да җитәкли башлый, шунлыктан, асылда, ике оешма бергә кушыла. «Р.п.-х.ж.» күп кенә мәсьәләләрдә башкаланың уң монархиячел оешмалары документларыннан (аерым алганда, җир биләүнең «община-хутор» моделен кертү тәкъдиме) үзгә караштагы үз программасын эшләп кабул итә, һөнәри белем бирүне үстерү б-н шөгыльләнә. Җәмгыять әгъзалары Казан губернасының иҗтимагый-сәяси тормышында (ш.и. Дәүләт Думасына барлык чакырылыш сайлауларда), монархиячел съездлар эшендә һәм башка чараларда актив катнашалар. 1906 ның 11 мартында Казандагы уң монархиячел оешмалар депутациясе составында «Р.п.-х.ж.»ннән сайланган вәкилләр дә Царское Селода император Николай II б-н очрашалар. 1910 ның 10 сентябрендә, Казанга килгәч, «Р.п.-х.ж.» депутациясен МС рәисе П.А.Столыпин кабул итә. Җәмгыять әгъзаларының карашларын «Черносотинец», «Сошники» г-талары һәм «Предвыборная газета» чагылдыра. 4 нче Дәүләт Думасына сайлауларда уңышсызлыкка тарыганнан соң (1912) активлыгы сүрелә барган «Р.п.-х.ж.»нең эшчәнлеге 1917 нең мартында туктатыла.

*Әд.:* А л е к с е е в И.Е. Русское национальное движение в Казанской губернии и Татарстане: конец XIX — начало XX веков (опыт словаря). К., 2004. *И.Е.Алексеев.*

**РУС ПРАВОСЛÁВИЕСЕНЕҢ ИСКÉ ДИН ТАРАФДАРЛАРЫ́ ЧИРКӘВЕНÉҢ КАЗÁН-ВЯ́ТКА ЕПÁРХИЯСЕ**, епископ җитәкчелегендәге чиркәү адм. бүленеше берәмлеге. 1856 елда Белокриницкий иерархиясенең Мәскәү иске дин тарафдарлары архиепископы Антоний (Шутов) тарафыннан Казан һәм Вятка епархиясенең беренче епископы *Пафнутийга* (Шикинга) рухани дәрәҗәсе бирелгәннән соң оештырыла. 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башында Казан һәм Вятка губерналары терр-яләре керә. 1905 нең 17 октябрь Манифесты игълан ителгәнгә кадәр епископлар рәсмиләштерелмәгән хәлдә яши. Төп яшәү урыннары Саратов губернасының Хвалынск шәһәре янындагы Черемшан монастыре була, Казандагы резиденцияләре рухани дәрәҗә бирелүче иске дин тарафдарлары храмы торган Карповлар йортына урнаша (хәзер Бауман урамы, 64). 1905 нең апреленнән соң Епархия идарәсе рәсми рәвештә яши башлый, 1909 да *Покров чиркәве* кафедраль собор итеп оештырыла. Епархиядә уннарча иске дин тарафдарлары приходы, ш.и. 20 дән артыгы Казан губернасы терр-ясендә эшли. Казан-Вятка епархиясе б-н идарә иткән епископлар: Пафнутий (1856–90), *Иоасаф* (Зеленкин) (1890–12), Филарет (Удалов) (1912–31). 1930 еллар башында динне эзәрлекләү башлангач, иске дин тарафдарлары иерархиясе структурасы гамәлдә яшәүдән туктый. Казан-Вятка епархиясе 1997 дә торгызыла. 2001–04 тә аның б-н Казан һәм Вятка епископы Андриан (Четвергов) идарә итә. 2005 тә Казан-Вятка епархиясе башлыгы булып епископ Корнилий (Титов) хезмәт итә. Хәзерге вакытта епархия Татарстан, Мордва, Мари, Чуаш һәм Удмурт Республикаларын; Киров һәм Ульянов өлкәләрен; Пермь краеның Чайковский шәһәрен үз эченә ала.

*Е.В.Липаков.*

**РУС САРАЛАНЫ́** посёлогы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 55 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 36 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөзнең 2 нче яртысына кадәр Татар Сараланы авылыннан күченгән руслар нигезли. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Р.С.нда укырга-язарга өйрәтү мәктәбе (1899 да ачыла), җил тегермәне, тимерче алачыгы, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире (Татар Сараланын да кертеп) 2647 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Саралан волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 161, 1897 дә — 286, 1908 дә — 299, 1920 дә — 302, 1926 да — 325, 1938 дә — 313, 1949 да — 253, 1958 дә — 129, 1970 тә — 110, 1979 да — 66, 1989 да — 49, 2002 дә — 32 кеше.

**РУС САРСАЗЫ́** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 26 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Дөреш елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 17 кеше (руслар) яши. 1874 тә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ташчишмә исеме б-н дә билгеле. Халкы игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1907 дә земство мәктәбе ачыла. 19 йөз ахырында авыл җәмгатенең имана җире 729,7 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязендә, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1887 дә — 322, 1905 тә — 361, 1920 дә — 417, 1926 да — 452, 1938 дә — 385, 1949 да — 328, 1958 дә — 542, 1970 тә — 109, 1979 да — 46, 1989 да — 14, 2002 дә — 17 кеше.

**РУС САРСАЗЫ́** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 27 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 2 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 27 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Покровский, Чистое Поле по речке Сарысаз исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына (Кама тимер эшкәртү з-дына беркетеләләр) керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Покров чиркәве (1879 да төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1880 нәрдә ачыла), 9 җил тегермәне, 2 тимерче алачыгы, 1 казна шәраб һәм 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4912,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Талкыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 231 ир-ат; 1859 да — 1052, 1897 дә — 2051, 1908 дә — 2224, 1920 дә — 2116, 1926 да — 1970, 1938 дә — 1762, 1949 да — 865, 1958 дә — 542, 1970 тә — 341, 1979 да — 225, 1989 да — 117, 2002 дә — 53 кеше.

**РУС СӘРӘНÉ** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 45 *км* көнбатыштарак, Баграж елгасы (Чишмәнең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 105 кеше (чуашлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1744 еллар тирәсендә нигез салына. 1920 елларга кадәрге чыганакларда Зур Сосновый Багряш исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, тер-

лекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Михаил-Архангел чиркәве (1888 дә төзелә), икмәк саклау-сату кибете, чиркәү-приход мәктәбе (1891 дә ачыла), 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 430,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Ерсубай волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1782 дә — 83, 1795 тә — 97, 1816 да — 126, 1834 тә — 174, 1859 да — 204, 1870 тә — 230, 1884 тә — 318, 1897 дә — 409, 1905 тә — 450, 1912 дә — 544, 1920 дә — 556, 1926 да — 347, 1938 дә — 362, 1949 да — 293, 1958 дә — 133, 1970 тә — 51, 1979 да — 87, 1989 да — 83, 2002 дә — 112 кеше.

**РУС СУЫКСУЫ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 21 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда даими яшәүчеләр юк. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Успенский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Успение чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе, 2 вак-төяклләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 153 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Әлки волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 85 ир-ат; 1859 да — 175, 1897 дә — 174, 1908 дә — 264, 1920 дә — 372, 1926 да — 320, 1938 дә — 251, 1949 да — 221, 1958 дә — 157, 1970 тә — 114, 1979 да — 46, 1989 да — 4, 2002 дә — 5 кеше (руслар).

**РУС ТАНАЕ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 45 *км* көньяк-көнбатыштарак, Гөбенә елгасы буенда. 2010 елда 6 кеше (татарлар, руслар) яши. 18 йөзнең 2 нче яртысына кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рус Мамадыш Тәүгелдесе исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 337,24 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1859 да — 172, 1897 дә — 292, 1908 дә — 339, 1920 дә — 338, 1926 да — 335, 1938 дә — 353, 1949 да — 145, 1958 дә — 99, 1970 тә — 67, 1979 да — 44, 1989 да — 14, 2002 дә — 7 кеше.

**РУС ТА́У ИЛЕ́** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 13 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Норма елгасы (Мишәнең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 1 кеше яши. 1646 дан Тау Иле буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ходяш исеме б-н мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (18 йөздә — М.Н.*Кудрявцевныкы*, крепостной хокук бетүгә 1 көн кала — княгиня Ухтомскаяныкы булып саналалар) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, буяу эшләре б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Пятница чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе (1890 да ачыла), су тегермәне, вак кредит учреждениесе, 3 бакалея һәм 1 вак-төякләр кибете була; Пасхадан соңгы 9 нчы җомгада ярминкә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 785 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Пановка волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 78 ир-ат; 1859 да — 612, 1897 дә — 820, 1908 дә — 687, 1920 дә — 553, 1926 да — 514, 1949 да — 200, 1958 дә — 204, 1970 тә — 138, 1979 да — 58, 1989 да — 17, 2002 дә — 3 кеше (татарлар).

**РУС ТЕЛЕ́**, рус халкының милли теле; РФнең дәүләт теле, ТРда ике дәүләт теленең (татар теле б-н беррәттән) берсе, Россия һәм БДБ илләрендә яшәүче халыкларның милләтара аралашу чарасы, Берләшкән милләтләр оешмасы (БМО) һәм ЮНЕСКОның эш теле. Һинд-европа телләре семьялыгына керә, славян телләренең көнчыгыш славян төркеменә карый. Дөньяда 260 млн. га якын кеше, ш.и. РФдә 138 млн. (барлык халыкның 99% чамасы) һәм якын чит илләрдә 80 млн. тирәсе кеше рус телендә сөйләшә (2010). Татарларның 85% тан күбрәге Р.т.н яхшы белә.

Морфологик төзелеше ягыннан Р.т. флектив, синтетик телләр төркеменә керә, форма ясалыш системасы көчле үсеш алган. Р.т.нең сүз байлыгы, нигездә, сүз ясалышы хисабына, ш.у. башка телләрдән кергән *алынмалар* б-н дә тулылана. Хәзерге Р.т., кешелек дөньясының барлык өлкәләрен дә үз эченә алып, семантик һәм стилистик яктан аерып каралган зур сүзлеккә, бай фразеология һәм паремиологиягә ия.

Р.т.ндә төп 2 шивәне аерып карыйлар: төньяк рус һәм көньяк рус. Аларның сүзлек составында, вокализм («а»лаштыру, «о»лаштыру), консонантизм (шартлаулы яки фрикатив «г») системаларында һәм грамматикасында (нигезләр кушылу, флексияләр омонимиясе, фигыльнең архаик формалары саклану һ.б.) аерма бар. Бу шивәләргә хас үзлекләрнең үзенчәлекле ярашуы урта рус сөйләшләрендә күзәтелә.

Хәзерге Р.т.нең нигезен әдәби тел тәшкил итә. Әдәби нормалар булу мәҗбүри санала, алар тел традицияләрен саклый, милләтнең рухи үсешендә күчемлелекне тәэмин итә. Р.т.ндә сөйләшүчеләрнең социаль яктан күптөрлелеге стиль бүленеше килеп чыгуга сәбәпче була (сөйләм, китап, ш.и. публицистик, фәнни һ.б. стильләр). Р.т.ндәге функциональ һәм стиль төрлелеге язма һәм сөйләм формаларында күзәтелә, лексикада, тел чараларын куллану рәвешендә аерым үзенчәлекләргә ия.

Рус әдәби теле үсешендә 5 этапны аерып карыйлар: борынгы рус әдәби теле (11–14 йөзләр), Рус дәүләтенең рус әдәби теле (14–17 йөзләр), рус милләте формалашу чорындагы әдәби тел (17 йөз — 19 йөз башы), рус әдәби теле (19 йөз), хәзерге рус әдәби теле. Рус әдәби теле нормалары 19 йөз ахырында — 20 йөз башында гомумруслыкы булып киткән Мәскәү сөйләше нигезендә эшләнә. Хәзерге әдәби телдә 42 фонема: 5 сузык һәм 37 тартык аваз бар. Р.т.нең аваз төзелеше тарихи үсеш кичергән вакытта сузык авазларның саны кими, ә тартыклар артып китә (борынгы рус телендә 11 сузык һәм 26 тартык була).

Табигате б-н рус язуы хәреф һәм авазлардан тора, рус алфавиты *кириллицага* нигезләнә. Хәзерге алфавитта 33 хәреф бар, шуларның 20 се тартык авазны белдерә. 1920–30 елларда рус алфавиты нигезендә СССРның элекке респ-каларының һәм Россиянең күп кенә телләренең алфавитлары үзгәртеп эшләнә. 1990 нан якын чит илләрдә һәм РФ субъектларында кириллица язуыннан файдалануны яңадан карау процессы башлана.

Остромир Евангелиесе, Изборниклар, Новгород хезмәт минеяләре (11 йөз), каен тузына язылган язмалар (11–15 йөзләр) рус язуының аеруча элгәреге ядкәрләреннән санала.

РФАнең В.В.Виноградов исем. Рус теле ин-ты, Мәскәүдә А.С.Пушкин исем. Дәүләт рус теле ин-ты, С.-Петербургта Лингвистик тикшеренүләр ин-ты Р.т.н өйрәнү буенча әйдәп баручы фәнни-тикшеренү үзәкләре булып торалар.

*Әд.:* Русская грамматика: В 2 т. М., 1980; Русский язык // Государственные и титульные языки России. М., 2002; Словарь русских народных говоров: В 40 вып. Л.-СПб., 1965–2006; Русский язык: Энцикл. М., 1997; Толковый словарь русского языка конца XX века: Языковые изменения. СПб., 1998.

*Р.Ә.Колшәрипова.*

**РУС ТИМЕРЛЕГЕ́** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 53 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тимерлек елгасы буенда. 2010 елда 8 кеше (руслар) яши. 17 йөз ахырында — 18 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда — Колчурин Тимерлеге, 1920–40 елларда Югары Тимерлек исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5305 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Әлмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 21 ир-ат; 1859 да — 187, 1897 дә — 348, 1908 дә — 427, 1920 дә — 532, 1926 да — 443, 1938 дә — 293, 1970 тә — 96, 1979 да — 106, 1989 да — 29, 2002 дә — 14 кеше.

**РУС ТӨГӘЛБАЕ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 22 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бизнә елгасы буенда. 2010 елда 4 кеше (татарлар, руслар) яши. 18 йөзнең

1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Бизнә исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе, җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 987 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Кузнечиха волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 63 ир-ат; 1859 да — 385, 1897 дә — 917, 1908 дә — 433, 1920 дә — 480, 1926 да — 289, 1938 дә — 172, 1949 да — 157, 1958 дә — 142, 1970 тә — 79, 1979 да — 52, 1989 һәм 2002 дә — 13 әр кеше.

**РУС УРМАТЫ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 26 *км* көнчыгыштарак, Казан–Пермь автомобиль юлы буенда. 2010 елда даими яшәүчеләр юк. 18 йөз ахырында алпавыт И.Ф.Еремеев нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Урмат, Теребиловка исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык һ.б. кәсепләр б-н көн күрә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1894 тә ачыла), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 331,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1859 да — 246, 1897 дә — 331, 1908 дә — 299, 1920 дә — 286, 1926 да — 326, 1938 дә — 232, 1949 да — 188, 1958 дә — 185, 1970 тә — 49, 1989 да — 34, 2002 дә — 2 кеше. Р.У. янында *Рус Урматы авыллыгы* урнашкан.

**РУС УРМАТЫ́ АВЫЛЛЫГЫ́** (археол.), Биектау р-ның Рус Урматы авылы янындагы 12–14 йөзләргә караган болгар торулыгы калдыклары. *Иске Казан тарих-мәдәният һәм табигать музей-саклаулыгы* составына керә. Р.У.а. истәлекләрен тикшерү 18 йөзнең 2 нче яртысыннан алып барыла: Н.П.Рычков (1770), И.Г.Георги (1773), М.С.Рыбушкин, Е.А.Малов, В.Л.Борисов, И.Н.Смирнов (19 йөз — 20 йөз башы), И.Н.Бороздин (1928), Н.Ф.Калинин (1945, 1951 елларда — археол. разведка казулары, 1956–57 дә — археол. казулар), Ә.Г.Мөхәммәдиев (1976), Р.Г.Фәхретдинов (Казансу елгасы бассейнына тулы археол. разведка, ш.и. 1969, 1976, 1977 дә Иске Казанның тирә-ягына; 1983 тә — археол. казулар) һ.б. Авыллык Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгының эре торулыкларыннан берсе була, шәһәрнең (ихтимал, *Камай шәһәрлегенең*) сәүдә-һөнәрчелек бистәсен тәшкил итә. Р.У.а.ның гомуми мәйданы 1,24 млн. *м*². Шәһәрлектән аермалы буларак, оборона ныгытмалары куелмый. Авыллык терр-ясендә торак һәм хуҗалык корылмалары (чүлмәк ясау һәм һөнәрчелек остаханәләре һ.б.) калдыклары ачыклана, эпиграфик истәлекләр, тимер һәм бакыр көнкүреш предметлары, хезмәт һәм сугыш кораллары, зәркән эшләнмәләр, көмеш һәм бакыр тәңкәләр һ.б. табыла. Археол. табылдыклар арасында иң зур күпчелекне әвәләп ясау һәм чүлмәк ясау түгәрәгендә эшләнгән балчык савытлар тәшкил итә (бер тимерче учагы янында гына да 10 меңнән артык керамика калдыклары булуы ачыклана), авыллыкның көньяк өлешендә — 12 йөз ахырына — 13 йөз башына караган керамика, төньяк өлешендә, шәһәрлеккә якынрагында, Алтын Урда чорына нисбәтле эшләнмәләр өстенлек итә (ш.у. ялтыравык керамиканы яндыру өчен ясалган учак урыны табыла, бу исә Урта Идел буеның төньяк районнары өчен техник яңалык булып тора). Археол. табылдыклар арасында нумизматик материал аеруча кызыксыну уята: хәлиф Насыйрлетдин исеменнән 1180 елларда сугылган тәңкәләр, 1280 еллар Җучиләр акчалары, Алтын Урда ханы Җанибәк дирһәме. 1951 дә Р.У.а. терр-ясендә, калын җир катламы астында, архаик формадагы (үлчәмнәре 145×35×15 *см*) эпиграфик истәлек — хәзерге көнгә кадәр сакланып калган иң борынгы болгар кабер ташы табыла. Ташның язулары (эпитафия), җирләү датасыннан (1284, һиҗри б-н 680) кала, начар сакланган (мәетнең исеме дә юк). Кабер ташы б-н янәшәдә язулары сакланмаган тагын бер таш була. Алар янында тагын шактый гына кабер ташлары кисәкләре булуы ачыклана. Иске Казан өчен генә түгел, бөтен Урта Идел буе өчен дә уникаль табылдык булып шомартылган сөяк каба исәпләнә, чит-читләрендәге тигез түгәрәк сызыклар аның станокта эшләнүе турында сөйли, өслегендә — биш почмаклы йолдыз сурәте, ул Евразиянең кайбер урта гасырлар халыклары истәлекләрендәге бизәкләргә хас.

*Әд.:* Шпилевский С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; Калинин Н.Ф., Халиков А.Х. Итоги археологических работ КФАН СССР за 1945–1952 гг. К., 1954; Фахрутдинов Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984.

*Р.Г.Фәхретдинов.*

**«РУС ХАЛКЫ́ БЕРЛЕГЕ́»**, 1905–17 елларда Россия империясендә эшчәнлек алып барган уң монархиячел (карагруһчыл) иҗтимагый-сәяси оешма. Революцион һәм либераль хәрәкәтләргә каршы көрәш максаты б-н төзелә, төрле катлау вәкилләрен берләштерә, ил буйлап бүлекләрен булдыра. «Православие. Самодержавие. Халыкчанлык» дигән өч өлештән торган принципка нигезләнгән идеологиягә таянып эш итә. Православие һәм патша самодержавиесен саклау һәм аларның һәр җирдәге хакимлеге, Россия империясенең бердәмлеге һәм бүленмәслеге, рус халкының өстенлекле халәтен ныгыту турындагы лозунгларны алга сөрә. Милли мәсьәләдә әҗнәбиләргә (бигрәк тә яһүдләргә) карата чикләүләр саклануын таләп итә. А.И.Дубровин рәислегендәге Баш совет (1 нче составка Казан губернасыннан земство эшлеклесе Н.Н.Языков та керә) тарафыннан идарә ителә.

«Р.х.б.»нең Казан губерна бүлеге 1906 ның ноябрендә ачыла (рәисе — проф. В.Ф.*Залесский*, бер үк вакытта Казандагы «Рус патша-халык җәмгыяте» рәисе). Бүлек, формаль рәвештә «Р.х.б.» уставы һәм документлары нигезендә идарә ителгән саналса да, гамәлдә киң автономиягә омтыла һәм, башлыча, җитәкчесенә ярашлы юнәлештә эш итә. Берлекнең Казан бүлеге сайлау кампанияләрендә, җыелышлар һәм манифестацияләр уздыруда, Казан губернасының шәһәр һәм өязләрендә җирле бүлекләр ачуда катнаша. Казан полицмейстеры мәгълүматларына караганда, 1907 нең 4 декабренә Берлекнең Казан губерна бүлеге 500 кешене берләштерә. 1906 ның ноябренең икенче яртысында Казандагы Адмиралтейство бистәсендә Боголюбский (Адмиралтейство) бүлеге ачыла (100–200 кеше; рәисе — сәүдәгәр А.И.Кукарников, бер үк вакытта Казан шәһәре чиркәү старосталары һәм приход попечительләре җәмгыяте Советы рәисе; 1910 ның маеннан — Н.М.Троицкий). 1906 ның декабрендә Казанда В.Ф.Залесский, А.И.Кукарников, «Рус җыены»ның Казан бүлеге Советы рәисе А.Т.*Соловьёв* һәм алар тарафыннан дүртенче әгъза итеп сайланган архимандрит *Андрей* (кенәз А.А.Ухтомский) составында «Берләшкән рус халкының өлкә идарәсе» оештырыла. Әмма барлык Идел-Кама төбәген үз карамагына алырга тиеш булган бу идарә гамәли эшчәнлеккә керешми, кәгазьдә генә кала. В.Ф.Залесский һәм А.Т.Соловьёв тырышлыгы б-н тиздән Казан губернасын «Р.х.б.»нең җирле бүлекләре челтәре чолгап ала. Казан губернаторы мәгълүматлары буенча, 1907 нең декабренә губернада берлекнең 97 бүлеге (7 меңләп кеше), ш.и. Казан, Арча, Зөя, Царёвококшайск, Цивильск һәм Чистайда 7 бүлек (1,2 меңләп кеше) эшли. 1908 нең октябрендә «Михаил Архангел исемендәге рус халык берлеге» (рәисе — укытучы, «Рус патша-халык җәмгыяте» һәм «Р.х.б.»нең элеккеге әгъзасы П.Ф.Мойкин) ачыла. Соңрак Михаил Архангел исем. берлекнең бүлекләре Казан губернасының кайбер өязләрендә, ш.и. «Р.х.б.» бүлекләре җирлегендә барлыкка килә. 1907 нең ахыры — 1908 нең башында, В.Ф.Залесскийның гамәлләре б-н риза булмыйча, «Р.х.б.»нең Казан губерна бүлегеннән 100 гә якын кеше чыга. Алар «Р.х.б.»нең Боголюбский бүлеге һәм Казан губернасында А.Т.Соловьёв һәм аның фикердәшләре ачкан башка оешмалар б-н берләшкән Пятницкий приходында (рәисе — Казандагы Спас-Преображение монастыре иеромонахы Софроний) «Р.х.б.»нең альтернатив бүлеген ачалар. Шулай итеп, «Р.х.б.»нең Казан губерна бүлеге Казан «Рус патша-халык җәмгыяте» һәм берлекнең В.Ф.Залесскийга турылыклы бүлекләре б-н берлектә «конкурентлар» лагеренда кала. 1908 нең 21–25 ноябрендә «Р.х.б.»нең Казан губерна бүлеге һәм җитәкчелеге шуның алдыннан гына А.И.Дубровин б-н демонстратив рәвештә араны өзгән Казан «Рус патша-халык җәмгыяте» Казанда Казан һәм башка губерналар «Р.х.б.»ләре-

нең 57 «провинциаль» бүлеге һәм монархиячел төрле оешма вәкилләре катнашында «Беренче Идел-Кама өлкә патриотик съезды»н уздыра (съездның шәрәфле рәисе — кенәз А.Г.Щербатов, рәисе — В.Ф.Залесский). Аның эш нәтиҗәләре буенча 8 резолюция кабул ителә (ш.и. «Руханилар һәм приход», «Җир төзелеше мәсьәләсенә карата», «Әҗнәбиләр мәсьәләсенә карата» һ.б.). Үз мөстәкыйль курсын алып барган В.Ф.Залесский һәм А.И.Дубровин яклы А.Т.Соловьёв арасында 1908–11 дә дәвам иткән каршылык нәтиҗәсендә «Р.х.б.»нең Казан губерна бүлеге җитәкчелек статусын югалта. 1911 нең мартында формаль яктан мөстәкыйль 2 оешма: «Казан рус халкы берлеге» (гамәлгә куючылары — В.Ф.Залесский, С.Т.Голубев, А.Е.Дубровский) һәм «Георгий Победоносец исемендәге Казан рус халкы берлеге» (гамәлгә куючылары — А.Т.Соловьёв яклылардан сәүдәгәр Ф.С.Гребеньщиков җитәкчелегендәге төркем) теркәлә. Рәсми рәвештә расланган икеүзәклелек элекке губерна бүлегенең юкка чыгуына китерә һәм җирле уң монархиячел хәрәкәтнең үзәкләштерелүенә чик куя. Акрынлап, «Р.х.б.»нең күпчелек бүлекләре таркалу хәленә килә. Берлектә, 1909–11 дә барган бүленеш нәтиҗәсе буларак, 1912 нең августында «Бөтенроссия дубровинчыл рус халкы берлеге» оеша (А.Т.Соловьёв провинциядән аның Баш советына әгъзалыкка кандидат итеп сайлана). Казан губернасындагы А.Т.Соловьёв күзәтчелегендә эш алып барган дубровинчыл «Р.х.б.» бүлекләре «Бөтенроссия дубровинчыл рус халкы берлеге» бүлекләре итеп рәсмиләштерелә. 1917 елгы Феврев-циясеннән соң «Р.х.б.» һәм башка уң монархиячел оешмалар эшчәнлеге тыела, берлек әгъзалары репрессияләргә һәм төрле җәберләүләргә дучар ителә. Ш.у.к. *Карагруһчылар*.


*Әд.:* А л е к с е е в И.Е. Чёрная сотня в Казанской губернии. К., 2001; ш у л у к. Русское национальное движение в Казанской губернии и Татарстане: конец XIX — начало XX веков (опыт словаря). К., 2004; Чёрная сотня: Ист. энцикл. 1900–1917. М., 2008. *И.Е.Алексеев.*

**РУС ХАЛЫ́К АРХИТЕКТУ́РАСЫ**, рус халык осталарының архитектура-төзелеш иҗаты. Казан төбәгендә 16 йөз уртасыннан киң тарала. Рус авылларында П-рәвешле утарлар төзелә (йорт һәм хуҗалык каралтылары ишегалды периметрына «П» хәрефе ясап урнашалар), ишегалды урам ягыннан капка-коймалар б-н корып алына. Йортларның күпчелеге агач буралардан төзелә, биек итеп эшләнгән аскы катлар хуҗалык ихтыяҗлары өчен файдаланыла, йорт, ак келәткә һәм кунак өенә бүленә, ярлы крәстиян йортларының аскы каты һәм кунак өе булмый. Шулай ук алты почмаклы йортлар да салына. Аларда йорт б-н кунак өе янәшә урнаша, ә ак келәтләрне өй каршына төзиләр. 18 йөз ахырыннан 19 йөзгә кадәр, Казан губернасының кайбер районнарында шактый соңрак та, бүрәнә фронтонлы йортлар һәм хуҗалык каралтылары очрый. Йорт түбәләре, хуҗаларның хәленә карап, салам, камыш, дранча, сирәк кенә табаклы калай б-н ябыла. Шәһәр архит-расы йогынтысында халык архит-расында такта фронтоннар һәм кәрнизләр барлыкка килә. Фронтоннар тимпанында йөзлекләре сырлап ясалган чарлак тәрәзәләре урнаша. 18 йөз ахырында — 19 йөзнең 1 нче яртысында Идел, Кама, Вятка елгалары буенда урнашкан авылларда өйләрнең түбә кәрнизләрендәге тәрәзә йөзлекләре, фронтон тәрәкләре, капка баганалары һәм канатлары еш кына үсемлексыман уеп ясалган барельефлы бизәкләр төшереп ясала. 19 йөзнең 2 нче яртысында – 20 йөз башында рус осталары торак йортларны бизәгәндә такта тышлыклар, ябыштыру һәм кисү алымнары б-н әзерләнгән декоратив элементлар куллана башлыйлар. Казан губернасының башка төбәкләрендә ш.у. йортка терәп салынган өсте ябулы хуҗалык каралтылары булган «кушма» типтагы утарлар төзелә. Кайвакыт каралты түбәсенең бер өлешен алынмалы итеп эшлиләр, һәм ул елның җылы вакытларында ачык тора. Рус авыллары йортларның кызыл сызыкка урнашуы б-н аерылып тора; йорт ишеге урам яктан керешле итеп төзелә. Кирпеч кибетләр өйнең беренче катына урнаша яки ишегалдына аерым корыла һәм аңа урамнан кереп йөрелә. Рус авылларында халык осталары агач чиркәүләр һәм кәшәнәләр дә төзиләр. Чиркәү квадрат бурадан өелә, ике кыеклы түбәгә барабанлы гөмбәз урнаштырыла. Чиркәү биналары еш кына «дүртлек өстенә утыртылган дүртлек», «дүртлек өстенә утыртылган сигезлек» тибында салына. Көнчыгыштан көнбатыш уңаена су-



1


2


3


4


5


6

**Рус халык архитектурасы.** 1. 20 йөз башы рус авылы. График реконструкция; 2. 20 йөз башы типик рус утары. График реконструкция; 3. Олы Ходяш авылы урамы. Яшел Үзән районы; 4. Кыркүл авылында Троица чиркәве. Алексеев районы. 2004; 5. Макаровка авылында торак йорт. Биектау районы; 6. Савиново посёлогында кое өсте кәшәнәсе. Казанның Яңа Савин районы.

зып төзелгән, бер үзәк буйлап храм үзе, аш бүлмәсе һәм чаң манарасы тезелгән «кораб» тибындагы чиркәү төре 19 йөздә — 20 йөз башында киң таралган була. Чаң манаралары берсе өстенә берсе кечерәя баручы ярус ясап утыртылган «дүртлек» һәм «сигезлек»ләрдән өелә һәм гөмбәзле чатыр түбә б-н ябыла. Совет хакимияте чорында Р.х.а. үзгәрешләр кичерә. Утарлар, байлар һәм таза тормышлылар, ш.у. ярлы катлау вәкилләре яшәгән йорт типлары юкка чыга. Ишегаллары ачык һәм ябык итеп корылган П-рәвешендәге традицион утарлар һәм хуҗалык корылмалары күп булмаган «кушма» утарлар сакланып кала һәм көнкүрештә әле дә булса киң кулланыла.

*Әд.:* Б у с ы г и н Е.П. Русское сельское население Среднего Поволжья. К., 1966; ш у л у к. Материальная культура русского населения Среднего Поволжья. К., 1986.

*Х.Г.Надыйрова.*

**РУС ХАЛЫ́К СӘНГАТЕ́**, көнкүреш әйберләрен иҗат итүгә юнәлдерелгән коллектив сәнгать эшчәнлеге; бизәлеш һәм сынлы сәнгать өлкәсе. Урта Иделдә 16 йөзнең 2 нче яртысыннан, Казан ханлыгы терр-ясе Рус дәүләтенә кушылганнан соң барлыкка килә башлый. Биредә Россиянең төрле төбәкләреннән кузгалган халык төпләнеп кала, шуңа күрә Р.х.с.ндә этнотөбәк үзенчәлекләре ачык чагыла һәм аерым төбәкләрдә өйдә җитештерү, һөнәрчелек, кәсепчелек формаларында халык сәнәгатенең аерым төрләре: *чигү*, тукучылык, агачка кисеп бизәк ясау, челтәр бәйләү, металлны нәфис эшкәртү (к. *Халык нәфис кәсепчелеге*) киң үсеш ала. Хатын-кызларның өй шөгыльләре арасында чигү, кәләшләргә бирнә әзерләүгә бәйле буларак, һәр җирдә таралыш ала (кияүгә чыкканнан соң, хатын-кызлар чигү б-н сирәк шөгыльләнгән); ш.у. йорт интерьеры һәм йола әйберләре, традицион өс киемнәре чигеп бизәлә. Чигү техникасының исәпләүле (киндер тукымадагы җепләр санына карап) һәм исәпләүсез (алдан билгеләнгән рәсем буенча) алымнары аеруча киң кулланыла. Төрле төбәкләрдә тукымага, җепләр санын санап, әвернәсыман чигү алымы тарала (хатын-кыз күлмәкләре һәм алъяпкычлары, сөлге бизәкләрендә). 20 йөз башында аны җиңелрәк техника — канвада чигү алмаштыра. Исәпләүле шома чигү алымы (тукыманың уң һәм сул якларындагы чигү әллә ни аерылмый) киң таралмый. Р.х.с.нә хас сирәкләндерелгән җепле (мережкаланган) тукымада чигү үрнәкләре (өслектәге өстәмә җеп яки шнурны каймалап ак җөй) Россиянең төньяк, төньяк-көнбатыш һәм югары Идел өлкәләреннән килеп урнашкан Төньяк-Көнбатыш Идел алды, Көнбатыш Кама алды авылларында, Татарстанның Казан яны районнарында очрый. Каймалап чигүдән башка аркау җепләре суырып алынган материалда чигү (мережкалау) үрнәкләре дә популяр була. Алар, башлыча, хатын-кыз киемнәрен, сөлге башларын бизәү өчен кулланыла. Исәпләүсез техника б-н чигү алымнарына тамбурлап (элмәкләп) һәм шома чигү төрләре керә. Беренчесе киергедә тарттырылган тукымада элмәкләрдән торган чылбыр рәвешендә кечкенә ыргак яки энә ярдәмендә чигелә. Исәпләүсез шома чигү техникасы (ул ирләр күлмәкләрен, пәрдә-кашагалар, эскәтерләр һ.б.ны чиккәндә кулланылган) соңрак барлыкка килә. Бизәк, гадәттә, бер яклап кына тукымага төшерелгән контур буенча чигелә. Тормыш циклындагы йолаларның (бәби туе, чукындыру, туй, мәет күмү, искә алу йолалары) мәҗбүри атрибуты булып хезмәт иткән сөлге рус крәстияннәре чигүенең төп объекты булып тора. Алар ш.у. торак интерьерында да мөһим роль уйный. Сөлгене көзгегә ураганнар, икона киотын, фоторәсемнәрне каймалаганнар, Күлмәк («җиңсәләр») һәм кыек ялгаулы (рус) сарафанны («баусызъ яки «баулы») берләштергән традицион костюмнар да чигеп бизәлгән. Бәйрәм киемнәрендә бизәкләр, гадәттә, аның изү һәм муентык өлешендә, җиңнәрдә урнаштырыла; гадирәк бизәкләр кайвакыт җиң б-н төп буйлар тоташкан урынга кушып тегелә. Чигү өчен кызыл җеп кулланыла (яки кара җеп б-н аралаштырыла). Хатын-кыз киемнәре комплексы алъяпкыч б-н тулыландырыла. Аны комачка чигелгән бизәк, зияк, челтәр бизәп тора. Ирләр костю-


















**Рус халык сәнгате.** 1. Барельефлы (сукыр) уеп бизәк төшерү фрагментлары — «русалка» белән «русловик». 19 йөз ахыры. Кама Тамагы районының Красновидово авылы; 2. Кисеп ясалган бизәк үрнәге. Кәрниз. 1980 еллар. Кайбыч районының Олы Подберезье авылы; 3. Сөлге. Чүпләмле туку техникасы. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы. Алабуга районының Лекарево авылы; 4. Бәйрәм киеме. Ефәк, бәрхет, синтетик тукыма, алтын һәм ефәк җеп. Тегү, чигү. «Карина» ательесы (Чаллы ш.). 2000; 5. Халык остасы Ф.Сучков. Кувшин. Үзле балчык. Бизәкләр. Питрәч районының Питрәч авылы; 6. Сөлге. Киндер. Җеп яки шнурны каймалап күпертмәле җөй чигү. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы. Яшел Үзән районының Әйшә авылы; 7. Т. А н ю т и н а. Сувенир әйберләр. Тукыма, киҗе-мамык һәм йоннан эшләнгән җеп. Әвернәле чигү. 2000 еллар; 8. Халык остасы А.Обрезкова. «Зилант». Шөлдерләр б-н челтәр бәйләү. 2000.

мында күлмәкнең җиң, итәк, яка читләре чигелә. Кайвакыт күкрәк турыпочмаклап чигелә. 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында бизәкле (еш кына ак җеп б-н каймалап чигелгән) эскәтерләр, пәрдә-кашагалар, мендәр тышлыклары киң кулланыла башлый; чигүле чаршаулар барлыкка килә. Чигү, һөнәр төре буларак (җөйләп һәм шома чигү техникасында), монастырьларда заказга эшләүче чигүче монахинялар иҗатында үсеш ала (хатын-кызларның эчке киемнәрен, күлмәкләрне һ.б.ны чигеп бизәү); «ак» чигүчеләр укалап чигү б-н дә шөгыльләнгәннәр.

Чигү б-н бергә, башлыча, Россиянең төньяк-көнбатыш өлкәләреннән Татарстанның Кама алды районнарына күчеп килүчеләр алып килгән чүпләмле тукучылык та камилләшә бара. Аның б-н, челтәр, тасма, өстәмә комач ялгаулар кушып, сөлге башларын бизәгәннәр. Туку һәм чигү бизәкләре килеп чыгышлары һәм барлыкка килү вакытлары төрле булган катлаулы элементлар комплексын (ромб мотивлары, үзәктә агач рәвешендәге хатын-кыз фигурасы һәм аңа төбәлгән кошлар яки атлардан торган сюжетлы композицияләр, үсемлек бизәкләре) тәшкил итәләр.

Р.х.с. төре буларак, челтәр бәйләү ш.у. Идел буена Россиянең төньяк-көнбатыш өлкәләреннән күченүчеләр б-н килә, әмма, чигү һәм тукучылыктан аермалы буларак, аерым төбәкләрдә үсеш ала (к. *Челтәр бәйләү*).

Р.х.с.нең агачка уеп бизәк ясау төре популярлык казана. Ул аеруча өч кырлы уелмалы техникада, интерьер элементларында, йорт кирәк-яракларында, савыт-саба, эш коралларында еш очрый. Орнаментта гади һәм өермәле түгәрәкләр, яфраксыман бизәк мотивлары өстенлек ала. Борынгы заманнарда капка баганалары, өй кыеклары (торак фронтоны конструкциясе элементлары) шул рәвешле бизәлгән, түбә җепсәсенә стильләштерелгән ат башы яки кош сурәтләре беркетелгән дип фаразлана. 19 йөзнең 1 нче яртысында, түбәнең бәпкәле конструкциягә күчүе һәм яңаклы тәрәзәләр барлыкка килү б-н, крәстиян каралты-курасы хәзерге сыйфатларга ия була бара. Өч кырлы уемлы бизәк техникасына барельефлы һәм йомык бизәк ясау төрләре алмашка килә (1860–1920 елларда үсеш ала): су кызлары, арысланнар, әкияти кошлар һ.б. сурәтләнгән композицияләрдә үсемлек сабаклары мотивлары файдаланыла. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында архит-ра декорында уеп бизәк ясауның яңа төре — пычкы б-н кисеп ясалган яссы яки үтәли кисеп ясалган бизәк барлыкка килә. Ул рус йорты бизәлешендә хәзерге көнгә кадәр өстенлек итә. Анда геом. формадагы, үсемлек һәм зооморф бизәкләр, фантастик аждаһалар, су кызлары, ике башлы кошлар, совет эмблемалары мотивлары һ.б. еш очрый. Модельләштерелгән бизәкләр барельефлы уеп ясалган бизәктән пычкы б-н кисеп ясалган яссы бизәккә күчеш формасы булып тора. Тышкы яктан ул барельефлы бизәкне хәтерләтә, әмма кисеп ясалган нигезе рельефлы эшкәртү юлы б-н башкарыла (киң таралыш алуы 1920–30 елларга туры килә). 20 йөз башында кыру станогында кырдырып эшләнгән бизәкләр барлыкка килә. Алар кыру эше алга киткән авылларда гына тарала. Кырдырылган кронштейннар б-н кәрнизләрне, тәрәзә йөзлекләренең ян өлешләрен һ.б.ны бизиләр. Уеп ясалган декор тәрәзә йөзлекләренә, кәрнизгә, фасад яссылыгына урнаштырыла, фронтоннарны бизәүдә файдаланыла (к. *Рус халык архитектурасы*), торак бизәү комплексында фасад һәм фронтонның фигуралы яки мозаик тышлыгы б-н ярашлы рәвештә кулланыла, металлдан кисеп ясалган детальләр, буяулар б-н тулыландырыла. Табаклы калайдан кисеп эшләнгән металл бизәкләр (алар б-н мич һәм яңгыр суы торбаларын бизәгәннәр) 20 йөз башында кулланыла башлый. Фигуралы йорт тышлыклары авыл архит-расында 20 йөзнең 1 нче яртысында барлыкка килә, ләкин ул 1960–80 елларда гына киң таралыш ала. Тышлыкның формалары күптөрле: «шашка», «чыршы», «ромб» һ.б. Гадәттә, фронтонның өске контуры буенча пар атлар, кошлар, аждаһа, җайдаклар, манаралар, йолдызлар һ.б. үрнәкләр рәвешендәге түбә кыегы композициясе урнаштырыла. Капка бизәү хәзерге көннәргә кадәр популяр санала; капка канатларына кисеп ясалган челтәр «кояш»лар, күп яфраклы эре чәчәкләр һ.б. фигуралар беркетелә. Кайбер районнарда ш.у. болдыр өсте кыеклары һәм ишек өслекләре дә бизәлә. Йорт бизәү елга буйларында, шәһәр яннарында, олы юл буендагы авылларда аеруча үсеш ала, ул крәстиян өйләре конструкцияләре һәм ш.у. матурлык турында карашлар үзгәрү процессында барлыкка килә. 19 йөздә — 20 йөз башында *халык нәфис кәсепчелегенең* җирле үзәкләре: Балык Бистәсе авылында зәргәрчелек һәм челтәр бәйләү (к. *Балык Бистәсе һөнәр-сәнгать остаханәсе*), Чабакса авылында тимерчелек (к. *Чабакса һөнәр-сәнгать остаханәсе*), Питрәч авылында чүлмәк ясау (к. *Питрәч чүлмәк ясау кәсепчелеге*). Хәзерге вакытта Р.х.с. традицияләре йортларга уеп бизәк төшерү, нәфис тукучылык (к. *Алексеев бизәкләп туку фабрикасы*), *чигү* төрләрендә үсеш ала.

20 йөз башыннан хәзерге көннәргә кадәрге чорда осталар эшләгән әйберләрдә шактый дәрәҗәдә индивидуальләштерү төсмерләре һәм этник сыйфатларны югалту сизелә. Фәкать А.П.Обрезкова хезмәтләре чыгарма булып тора, ул Нырты челтәр бәйләү осталарының бәйләү һәм чигү техникасын кабаттан яңарта. Башлыча рус халкы арасында иҗади мөмкинлекләрне тормышка ашыру ихтыяҗы югары дәрәҗәдә саклана, бу ш.у. шәһәрләрдә һәм авыл җирләрендә төрле күргәзмәләр оештырылып тору б-н дә раслана.

*Әд.:* Воробьёв Н.И., Бусыгин Е.П. Художественные промыслы Татарии в прошлом и настоящем. К., 1957; Бусыгин Е.П. Русское сельское население Среднего Поволжья. К., 1966; Бусыгин Е.П., Зорин Н.В., Токсубаева Л.С. Декоративное оформление сельского жилища в Казанском Поволжье. К., 1986; Токсубаева Л.С. Русская народная художественная традиция в Казанском Поволжье // Расы и народы: Современные этнические и расовые проблемы: Сб. статей. М., 2003.

*Л.С.Токсубаева.*

**РУС ЧАБАКСАРЫ́** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 21 *км* көнбатыштарак, Чабаксар елгасы буенда. 2010 елда 152 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Никольский, Чабаксар буларак билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегермәнчелек һәм йон-тукыма ману б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Никольский чиркәве (1875–83 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1873 тә ачыла), фельдшерлык пункты, 10 җил тегермәне, 2 сыраханә, 1 шәраб кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 6749 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Изгар волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 427 ир-ат; 1859 да — 1415, 1897 дә — 2695, 1908 дә — 2909, 1920 дә — 3226, 1926 да — 2661, 1938 дә — 549, 1949 да — 442, 1958 дә — 600, 1970 тә — 696, 1979 да — 471, 1989 да — 229, 2002 дә — 232 кеше.

**РУС ЧИЯБАШЫ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 37 *км* көньяктарак, Шыя елгасы буенда. 2010 елда 88 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1690 елларда нигез салына; 1920 елларга кадәр, Татар Чиябашы авылы б-н берләштерелеп, Чиябаш дип йөртелә. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Починок Рысов, Рысова Поляна исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегермәнчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Чиябаш авылында Сергий Радонежский чиркәве, иске дин тарафдарлары гыйбадәтханәсе, 2 мәчет, земство мәктәбе, кредит ширкәте, 13 тегермән, 14 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4293 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Юхмачы волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 188 ир-ат; 1859 да — 1379, 1897 дә — 2379, 1908 дә — 2783, 1920 дә — 1490, 1926 да — 1122, 1938 дә — 589, 1949 да — 546, 1958 дә — 420, 1970 тә — 290, 1979 да — 201, 1989 да — 105, 2002 дә — 91 кеше.

**РУС ШАРШАДЫСЫ́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 38 *км* көньяктарак, Иж елгасы буенда. 2010 елда 61 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 82%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 1857 дә Татар Шар-

шадысы авылыннан (хәзер Шаршады а.) күченүчеләр нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Р.Ш.нда чиркәү, чиркәү-приход мәктәбе эшли. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 883,1 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Мөшәк волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерже, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерже, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерже р-нында. Халык саны: 1858 дә — 180, 1887 дә — 630, 1905 тә — 798, 1920 дә — 813, 1926 да — 358, 1938 дә — 531, 1958 дә — 232, 1970 тә — 149, 1989 да — 103, 2002 дә — 82 кеше.

**«РУС ШВЕЙЦА́РИЯСЕ»**, 19 йөздә — 20 йөз башында Казанның төньяк-көнчыгыш чите — Казансу елгасының сульяк ярындагы күңел ачу, ял итү урыны. Шул исемне алуына С.Т.Аксаковның дусты студент Н.И.Панаевның «Аркадские пастушки» кульязма ж-лында дөнья күргән, гүзәл табигате Н.М.Карамзинның «Рус сәяхәтчесе хатлары»нда («Письма русского путешественника») тасвирланган Швейцарияне хәтерләткәнгә күрә «Швейцария Казанда» («Швейцария в Казани») дип аталган мәкаләсе (1806) сәбәпче була. «Р.Ш.»н мәйданы 29 дисәтинә чамасы тәшкил иткән, ерганаклар б-н кискәләнгән урман каплап тора, Казансу үзәненә текә киртләчләр алып төшә. «*Немец Швейцариясе»ннән* куртина (Арча зираты) б-н бүленә. 1830 еллар уртасына «Р.Ш.» Казан җәмәгатьчелеге тарафыннан таныла. Казанга 1837 дә — Александр Николаевич (булачак император Александр II), 1866 да Александр Александрович (император Александр III) килү хөрмәтенә оештырылган гомумхалык бәйрәмнәре, Троица атнасы күңел ачулары бирелә ту үткәрелә. Шулай ук тамаша урыннары, трактир, кухня һәм буфетлы галерея төзелә, таганнар, балаганнар эшли. 1840 еллар башыннан, губернатор С.П.Шипов үзенең җәйге резиденциясен шунда күчергәннән соң, «Р.Ш.» дачалар төзү өчен файдаланыла. Урман чистартыла, сукмаклар салына, чәчәк түтәлләре ясала. 1870 еллар башында элекке губернатор дачасы Казан сәүдәгәрләр клубының һәм җәмәгатьчелекнең җәйге ял урыны буларак файдаланыла. Ресторанның ачык сәхнәсендә җырчылар, куплетчылар, нәфис сүз осталары чыгыш ясый. Кичләрен бакчада музыка уйный, фейерверклар, карнаваллар, кышларын тройкада йөрү, тимераякта шуу оештырыла. 1873 тән И.Митрофанов фотографиясе эшли башлый. Гомумхалык бәйрәмнәрендә гаилә эгъзалары бергәләп күңел ача. Табигатьтә чәй эчеп хозурланырга теләгәннәр үз самоварларын алып киләләр яки прокатка алып торалар. «Р.Ш.» ш.у. студентлар, чиновниклар, Казан аксөякләренең яраткан ял урынына әверелә. Казан халкының бирегә атлы тимер юл б-н килү мөмкинлеге була (Черек күл — Арча кыры юнәлеше). 1909 да «Р.Ш.»ндә Халыкара күргәзмә павильоннары ачыла. 1935 тә бу терр-яләр *Үзәк мәдәният һәм ял паркы* составына кертелә.

*Әд.:* З а г о с к и н Н.П. Очерки города Казани и Казанской жизни в 40-х годах. К., 2003; И д р и с о в а Р.Р. По старым улицам Казанским... К., 2005.

*М.В.Недорезов.*





Казанда «Рус Швейцариясе» паркы.
1. Паркка керү юлы; 2. Ачык сәхнә күренеше.
20 йөз башы фоторәсеме.

**РУС ШУГАНЫ́** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 16 *км* көньяктарак, Шуган елгасы буенда. 2010 елда 511 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Земство мәктәбе бинасы — 20 йөз башы архит-ра истәлеге. 17 йөз ахырында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Акайкүл исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4493 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Кармалы волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1897 дә — 2481, 1920 дә — 2867, 1926 да — 2240, 1938 дә — 1624, 1949 да — 1394, 1958 дә — 883, 1970 тә — 915, 1979 да — 772, 1989 да — 604, 2002 дә — 619 кеше.

**РУС ШЫРДАНЫ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 12 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сәкел елгасы буенда. 2010 елда 32 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. 16 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Петропавловский, Ширдан исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Петропавел чиркәве (1784 тә төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе, 3 тегермән, 1 чәйханә һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 264 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Шырдан волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Нурлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 123 ир-ат; 1859 да — 372, 1897 дә — 419, 1908 дә — 353, 1920 дә — 327, 1926 да — 360, 1938 дә — 388, 1949 да — 270, 1958 дә — 202, 1970 тә — 126, 1979 да — 79, 1989 да — 60, 2002 дә — 53 кеше.

**РУС ЫНДЫРЧЫСЫ́** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 13 *км* төньяктарак, Бөя елгасы буенда. 2010 елда 4 кеше (руслар, чуашлар) яши. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Ындырчы, Воскресенский исемнәре б-н дә билгеле. 1930 елларга кадәр Ындырчы исемен йөртә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Воскресение чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе, җил тегермәне, ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 626 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Шәмбалыкчы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 49 ир-ат; 1859 да — 190, 1897 дә — 340, 1908 дә — 430, 1920 дә — 402, 1926 да — 500, 1938 дә — 278, 1949 да — 230, 1958 дә — 129, 1970 тә — 71, 1979 да — 90, 1989 да — 9, 2002 дә — 7 кеше.

**РУС ЮРТАКЛАРЫ́ ТОКЫМЫ́**, Россиядә Орлов юртаклары токымын Америка юртаклары б-н кушудан барлыкка килгән атлар. Россиянең атаклы ат заводларында ферма-көтүлек шартларында тотылып, концентратлар б-н интенсив тукландырылган, төгәл бонитировка сакланган хәлдә, тренинг һәм ипподром сынауларына иртә җәлеп ителеп үрчетелгән яшь юртаклар арасыннан иң яхшылары аерып алына. Атлар елдамлык, экстерьер (тышкы) һәм башка күрсәткечләр буенча токымда иң яхшы сыйфатларны беркетү максатыннан сайлана. Яңа токым булдыру өч этапта алып барыла: 1 нче этап (1890–1914) — Америка юртакларын Орлов бияләре б-н кушу; 2 нче этап (1914–27) — кушылгакларны үзара кушу һәм кабаттан аларны һәм Америка бияләрен Орлов юртаклары б-н кушу; 3 нче этап (1927–49) — кушылгаклар (Орлов һәм Америка токымнары) б-н эшләү, аларны үз төрләре эчендә үрчетү. Шул юл б-н Орлов юртакларыннан төп күрсәткечләр буенча өстен — елдам, эре, көчле токым чыгарыла.

Р.ю.т.на караган ат какча конституцияле, камил корпуслы, нык сөякле, көчле һәм киң савырлы булуы б-н аерылып тора. Башы кечкенә, туры яки аз гына күперенке профиль-

ле; муены туры, мускуллы; җилкә калкымы биек; күкрәк читлеге тирән; аяклары нечкә, нык; ялы һәм койрыгы уртача кабарынкы. Күбесенчә кара туры, җирән һәм күк төстәгеләре очрый. Тышкы кимчелекләреннән алгы аякларының аерчаланып, арткы аякларының «камытланып» торуы, кыска һәм салынкы савырлы булуы кебек сыйфатларын күрсәтергә мөмкин. Холкы тыныч, җитез темпераментка ия. Рус юртагы нәсел аты буларак һәм спорт ярышлары өчен иң кулай санала. Тиз җитлегә, физиол. өлгереше, нигездә, 4 яшьләрдә тәмамлана. Елгырлык классы 2 *мин* 30 *с* булган атларның яртысыннан артыгы әлеге күрсәткечкә 3–4 яшьләрдә якынлаша. Рекордлы күрсәткечләргә 5–6 яшьләргә һәм соңрак ирешелә. 1975 елда СССР күләмендәге абс. рекордларның абс. күпчелеге рус юртаклары тарафыннан куела: 1600 *м* — 58,8 *с* (Колчедан), 2400 *м* — 3 *мин* 3 *с* (Павлин), 3200 *м* — 4 *мин* 6,1 *с* (Павлин).

Р.ю.т. атлары селекция эше б-н шөгыльләнүче дәүләт нәсел з-длары һәм фермалары, башка төр хуҗалыклар тарафыннан нәсел яхшырту өчен, ш.у. чабышкы ат буларак спорт ярышларында актив файдаланыла. Рус юртаклары — Россия ат з-дларында үрчетелә торган атларның иң күпсанлысы. Рус юртаклары үрчетүче иң зур заводлар — «Локотский» (Брянск өлкәсе), «Чувашский», «Троицкое» (Орёл өлкәсе), «Дубровский» (Чиләбе өлкәсе). Аларны ш.у. Краснодар һәм Ставрополь крайларында, Ростов өлкәсендә, Украина, Белоруссия һ.б.да үрчетәләр. Р.ю.т.н үрчетү б-н Нурлат р-нының «Нурлат», Питрәч р-нының «Казанский» дәүләт нәсел з-длары һәм милек формаларының башка төрләренә караган күп кенә хуҗалыклар шөгыльләнә. Илл.ләрне *Ат асраучылык* мәкаләсеннән кара.

*Әд.:* К о з л о в С.А., П а р ф ё н о в В.А. Коневодство. СПб.–М.–Краснодар, 2004.

*Ә.Х.Фазылҗанов, М.Г.Миролюбов.*

**РУС ЯБАЛАГЫ́**, к. *Ябалак.*

**РУС ЯЛТАНЫ́** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 33 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасы буенда. Даими яшәүчеләр юк. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Новопоселённая Елтань исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе (1885 тә ачыла), 2 җил тегермәне, тимерче остаханәсе, 1 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 418 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Изгар волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 60 ир-ат; 1859 да — 388, 1897 дә — 523, 1908 дә — 419, 1920 дә — 471, 1926 да — 466, 1938 дә — 395, 1949 да — 185, 1958 дә — 118, 1970 тә — 39, 1979 да — 30, 1989 һәм 2002 дә — 2 шәр кеше (руслар).

**РУС-А́ЗИЯ СӘҮДӘ́-СӘНӘГА́ТЬ КОММЕ́РЦИЯ БА́НКЫ**. 1910 елда Рус-Кытай һәм Төньяк банклары кушылудан барлыкка килә. 1914 кә банкның үз капиталы — 78 млн. сум, төп пассивлары — 629 млн. сум, төп активлары 672 млн. сум тәшкил итә. Банк, нигездә, хәрби, нефть һәм тәмәке сәнәгатен финанслый. 102 ф-лы (ш.и. Казанда да) була. Казан бүлегенең 1912 елгы капитал әйләнеше 4,8 млн. сум чамасы исәпләнә. 1917 дә национализацияләнә.

*Әд.:* Б о в ы к и н В.И., П е т р о в Ю.А. Коммерческие банки Российской империи. М., 1994.

**РУСАКО́В** Климент Сергеевич (4.2.1904, Казан губ., Лаеш өязе Уракчы а. — 1996, Украина ССР, Винница ш.), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), полковник. Мәскәү пехота мәктәбен (1942), командирлар составы белемен күтәрү курсларын (1943), М.В.Фрунзе исем. Хәрби акад. каршындагы командирлар әзерләү курсларын (Мәскәү, 1947) тәмамлый. Ярославль шәһәрендә заводта эшли. 1921–37 елларда һәм 1941 дән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 240 нчы укчы полк командиры (69 нчы армиянең 117 нче укчы дивизиясе). Воронеж, Дала һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Харьков һөҗүм һәм оборона операцияләрендә (1943), Днепр елгасы өчен сугышта (1943), Люблин-Брест (1944) һәм Варшава-Познань (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Висла елгасын кичеп, Пулавы шәһәре (Польша) янында плацдармны алуда батырлык күрсәтә: 1944 нең 31 июль төнендә Р. җитәкчелегендәге полк, кисәк һөҗүм итеп, мөһим стратегик пунктны ала, дошманның күпсанлы контратакаларын кире кайтара һәм күпләгән солдатын юк итә. 1957 дән запаста. Винницада яши. Ике Ленин ордены, дүрт Кызыл Байрак, 3 нче дәрәҗә Суворов, Александр Невский, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*



К.С. Русаков.

**РУСЕ́ЦКИЙ** Иосиф Иосифович (23.2.1891, Новочеркасск ш. — 14.11.1964, Казан), невропатолог, мед. фән. д-ры (1925), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1940, 1947). Проф. А.В.Фаворский шәкерте. Казан рефлексотерапия мәктәбенә нигез салучы. Париж ун-тын тәмамлый (1914). 1920 елдан Казан ГИДУВында, 1930 дан нерв авырулары каф. мөдире һәм профессоры. Акупунктура (чжен-дзю-терапия) буенча Кытайда стажировка уза (1956). Хезмәтләре вегетатив нерв системасын, хәрәкәтләнү һәм рефлекс системасы патологиясен, авырту тою проблемаларын өйрәнүгә карый. Р. үз исеме б-н аталган берничә авыру симптомын тасвирлый. Рефлексометр конструкциясен эшли, миосклерометр тәкъдим итә. Бөтенсоюз невропатологлар һәм психиатрлар җәмгыятенең Казан ф-лы рәисе (1932–64). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Боль, её формы и патогенез. К., 1946; Клиническая нейровегетология. М., 1950; Конструктуры конечностей. М., 1954; Вегетативные нервные нарушения. М., 1958.

*Әд.:* Профессор И.И.Русецкий // Казан. мед. журн. 1961. № 2.

**«РУСИ́Я СӘҮДӘСЕ́»**, икътисади журнал. 1912 елның октябреннән 1917 гә кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә. Нашире һәм мөхәррире Ш.Шәрифуллин, сәркәтибе Ш.Байчура. Актив авторлар арасында — Х.Әмиров, М.Айраш, Г.Гафуров, Г.Насыйбуллин, С.Рахманкулов, Ш.Хөсәенов. Басманың максаты — татар эшмәкәрләренә һәм татар җәмгыятенә икътисади белемнәр үзләштерергә ярдәм итү. Редакция илдә сәнәгатьне үстерүне, сәнәгый җитештерүнең төп



«Русия сәүдәсе» журналы.

тармакларын булдыруны яклый, чит ил капиталы йогынтысына каршы чыга. Материалларда татар милли капиталы тупланышы процессы, сәүдә йортлары һәм акц. җәмгыятьләр оештыру уңай бәяләнә. Татар буржуазиясенең Идел буе өлкәсеннән читкә экспансиясе билгеләп үтелә. Журнал фикеренчә, ул зур башкала һәм вак төбәк бизнеслары арасындагы көндәшлек, сәяси-адм. чикләүләр б-н бәйле була. Редакция татар капиталы кулланылышы өлкәсе киңәюне, аның структурасы баюны, татар эшмәкәрләренең алтын чыгару, текстиль, мех һәм сабын кайнату сәнәгате, ресторан бизнесындагы уңышларын хуплый. Кооперациягә һәм кооперация хәрәкәтенә багышланган мәкаләләр сериясе басыла, җитештерү кооперациясе, крәстияннәрнең товарларны сату һәм алу буенча ассоциацияләргә берләшүе уңай бәяләнә. Журнал укучыларны Көнбатыш илләрендәге кооперация тарихы һәм Скандинавия тәҗрибәсе б-н таныштыра. Табигый-фәнни характердагы, татар җәмгыятенең мәдәни дәрәҗәсен күтәрүгә өндәгән мәкаләләр басыла.

*Әд.:* Г а з и з у л л и н Ф.Г. Становление и развитие социально-экономической мысли татарского народа. СПб., 2004.

*Р.А.Айнетдинов.*

**РУСЛА́Р** (үзатама), РФдә көнчыгыш славяннар төркеменә караган иң күпсанлы халык. Россиядә аларның гомуми саны — 111 млн., ш.и. ТРда 1,501 млн. кеше (2010). Туган телләре — *кириллицаның* бер вариантыннан гыйбарәт алфавитлы *рус теле*. Башлыча, православие динен тоталар (988 елдан). Фаразланганча, атамалары Скандинавиядән килгән русь кабиләсе б-н бәйле. Кабилә кенәзе Рюрик һәм аның варислары Киев кенәзлеген (Киев Русен) төзиләр. Борынгы рус дәүләте җирлегендә 13–15 йөзләрдә 3 төркемгә (белоруслар, украиннар һәм Р.) бүленгән бердәм этносәяси берлек оеша. Төрле этник процесслар нәтиҗәсендә Р.ның төньяк, көньяк һәм урта (урта рус) этнотерр. төркемнәре барлыкка килә; Идел буендагы рус халкы урта төркемнең үзенчәлекле астөркеме буларак аерып күрсәтелә.

Хәзерге Татарстан терр-ясенә Р. 10 йөздә, Идел-Балтыйк сәүдә юлы барлыкка килү нәтиҗәсендә, килеп урнаша башлыйлар. Аларның, башлыча, сәүдә-һөнәрчелек эшчәнлеге б-н бәйле кечерәк төркемнәренең төбәктә гомер кичерүе археол. истәлекләрдә (*Ага-Базар, Биләр шәһәрлеге, Болгар шәһәрлеге*, «Муром шәһәрчеге») чагылыш таба. Р.ның Урта Идел буендагы беренче торулыклары Алтын Урда чорына (13–15 йөзләр) карый. Казан ханлыгы чорында Идел һәм Чулман алдында беренче рус авыллары барлыкка килә. Идел буе Рус дәүләте тарафыннан яулангannan соң, 1556 дан Р.ны элеккеге Казан ханлыгы җирләренә күчереп утырту процессы башлана. Массачыл *колонияләштерү* Рус хөкүмәтенең сәясәтеннән риза булмаган җирле халыклар кузгалышлары (к. *Казан җирләрендә азатлык сугышлары (1552–56), Казан ханлыгы яулангannan соңгы фетнә-чуалышлар*) тарафыннан өлешчә тоткарлана. 16 йөзнең 2 нче яртысында — 17 йөз башында рус колонияләштерүе чикләнгән хәлдә, башлыча, монастырьлар (аларга, күченеп килүчеләрне җәлеп итү өчен, җир кишәрлекләре һәм төрле ташламалар бирелә) һәм йомышлылар (яңа төзелгән *Зөя* (1551), Чабаксар (1555), *Лаеш* (1557) кальгаларына һ.б.га күчереп утыртылган хәрбиләр) биләве рәвешендә була. Татарлар куылган җирләрдә — шәһәрләр, кальгалар, җәмәгать округлары тирәсендә, ш.у. зур елгалар (Идел, Чулман) ярлары буйлап — патша сарае рус авыллары (к. *Патша сарае крәстияннәре*) барлыкка килә. Урта Идел буенда Р.ның саны ш.у. рус булмаган халыкларны *христианлаштыру сәясәте* һәм *руслаштыру сәясәте* уздырылу (к. *Керәшен татарлар*) хисабына арта. Рус авыллары Чулман алды һәм Чулман арьягының эчкәре районнарында да, татар, чуаш, мордва авыллары янәшәсендә дә корыла. Алар, «рус» сыйфатламасы өстәлеп, еш кына күршедәге рус булмаган халык яшәгән авыл исемен алалар: Рус Янтыгы, Рус Әхмәте, Рус Исламы һ.б. Р., башлыча, илнең төньяк, үзәк һәм Югары Идел төбәкләреннән күчеп утыралар. Рус халкы санының кискен артуы Рус дәүләтенең көньякта чикләре киңәю һәм чик сызыклары (Иске Кама арьягы чик сызыгы, Яңа Кама арьягы чик сызыгы һ.б.) корылу б-н бәйле. Бу Р. миграциясенең яңа дулкынына, Чулман арьягының көнбатыш һәм көнчыгыш төбәкләрен колонияләштерүгә китерә. 20 йөздә, халык хуҗалыгын индустрияләштерү, бөтенсоюз төзелеше (*КАМАЗ*, «*Түбәнкаманефтехим*» һ.б.) чорларында, Татарстан терр-ясенә русларның яңа төркемнәре килеп төпләнә. Әмма бу чорда, *Куйбышев сусаклагычын* төзү вакытында җирләрнең су астында калуы сәбәпле, рус торак пунктларының саны кими.

Рус халкының төп шөгыле игенчелек була. Хуҗалыкта тимерчелек, балыкчылык, бакчачылык, йорт кәсепләре зур роль уйный. Р. элек-электән олаучылык, бигрәк тә ерак араларга йөкләр ташу б-н шөгыльләнәләр. Казан губернасының төньяк районнарында урман кәсепләре — урман кисү, сумала һәм дегет куу, күмер яндыру һ.б. киң тарала. Рус крәстияне тормышына авыл җәмәгате зур йогынты ясый. Җәмәгать вазифасына җир (сөрүлекләр, болыннар), урман кишәрлекләре бүлү, юллар салу, гаилә мөлкәтен бүлүдә бәхәсләрне хәл итү һ.б. керә. Урта Идел буенда Р.ның йортлары, мәс., Төньяктагы, Урал, Себердәге йортлар б-н чагыштырганда, зур булмый, алар торак һәм хуҗалык корылмаларын берләштерә. Төзелештә агач киң кулланыла; башлыча, бүрәнә-бура йортлар, аларның фасадлары сырлап бизәлә (бигрәк тә 19 йөзнең 2 нче яртысында таралган биек рельефлы һәм катлаулы рәсемле «корабль бизәге» аерылып тора).

Р.ның Пётр I заманына (18 йөз) кадәрге киеменә формалар тотрыклылыгы, традицияләрнең саклануы һәм аерым үзенчәлекләр хас була: ирләр, гадәттә, йон, җитен һәм киндер тукымалардан туника рәвешендә тегелгән күлмәкне чалбар эченә кыстырмыйча кияләр, билбау буалар; өске киемнәрдән сырма, кафтан, чикмән, әрмәкләр (сарык йоныннан кафтаннар), толып, туннар киң тарала. Рус авылларында, бигрәк тә ярлы крәстияннәр арасында, чабата төп аяк киеме була, аларны җәенке башлы, биек кырыйлы итеп кыйгачламыйча курыстан үрәләр. Җәен чабатаны — киндер, кышын постау чолгаулар (ыштырлар) б-н кияләр, бау б-н бәйлиләр. Шулай ук «табаннар» («ступни», галош рәвешендә үрелгән аяк киеме) киеп йөриләр; итек бәйрәмнәрдә киелә. Ирләрнең баш киемнәре төрле — түгәрәкләнгән очлы конуссыман киез калфак, цилиндр рәвешле эшләпәләр һ.б. Хатын-кызларның традицион өс киеме чигеп бизәлгән зур җиңле озын күлмәктән гыйбарәт була, аның өстеннән сарафан кияләр, кагыйдә буларак, сарафан өстеннән билләренә яки култык асларыннан запон — озын алъяпкыч бәйлиләр. Кызлар башларына каты аслыклы кокошник, хатыннар кика кияләр. Шулай ук киҗе-мамык, йон, ефәк, гәреч (нәзек йоннан, сатып алынган) яулыклар, кечкенә шәлләр тарала. Хатын-кызларның аяк киемнәре ирләрнекеннән аз аерыла. Идел буенда яшәгән Р. җирле халыклардан халат рәвешендәге һәм җиңсез өс киемнәренең кайбер төрләрен, күн галошлы киез аяк киемнәрен, татар бүрекләрен, башкорт малахайларын үзләштерәләр. 18 йөздә — 20 йөз башында өс киемнәре акрынлап үзгәреш кичерә. Рус милли костюмы (бигрәк тә аксөякләрдә һәм шәһәр халкы арасында) күбесенчә Көнбатыш Европа үрнәкләре буенча эшләнә башлый.

Р.га аш-су әзерләүдә продуктларның киң ассортиментын куллану, төрле ысуллар хас. Икмәк, камыр һәм ярма ризыклары, яшелчәләрдән бәрәңге, кәбестә, кыяр өстенлек итә. Җиләк-җимешне крәстияннәр җимеш бакчалары күп булган кайбер җирләрдә генә, башлыча, Идел алды төбәгендә кулланганнар. Азык-төлек сыйфатында һәм дәвалау максатында үсемлекләр һәм үләннәр (кычыткан, алабута, кузгалак, сәрдә, балтырган, әрекмән тамыры һ.б.) файдаланылган; алардан сыек ризыклар әзерләгәннәр, төелгән орлыкларын икмәк пешергәндә онга өстәгәннәр. Шулай ук гөмбәләр (ак гөмбә, баллы гөмбә, усак гөмбәсе, каен гөмбәсе һ.б.) кулланылган; аларны кыздырганнар, тозлаганнар, киптергәннәр, гөмбә ашы пешергәннәр. Ит куллану озын постлар һәм атналык пост көннәре б-н чикләнгән; ит еш кына балык (ярым пост ризыгы) б-н алмаштырылган. Р.да икмәк квасы, кесәл, сыра, 19 йөздән чәй традицион эчемлек булып исәпләнгән. Ризыкны мичтә, башлыча, иртән әзерләгәннәр, шул сәбәпле көн дәвамында мич җылылыгы сакланган. Продуктлар саклау һәм ризык әзерләү өчен файдаланылган традицион йорт кирәк-яраклары чуен казаннан, чуен, тимер чүмеч, ухват һәм пычаклардан гыйбарәт булган; башка әйберләр балчыктан, агач, курыс һәм саламнан эшләнгән.

Православие, ш.у. борынгырак мәҗүси күзаллаулар б-н бәйле календарь теркәүле йолаларны, бәйрәмнәрне (Рождество, Пасха, Троица, чиркәү бәйрәмнәре, Каравон, Масленица) үтәү, уздыру зур әһәмияткә ия булган. Крәстиян гаиләсе тормышында гаилә бәйрәмнәре (аларның иң зурысы — туй) мөһим урын биләгән. Р.да өйләнешү игенчелек һәм чиркәү календарьларының билгеле бер чорларына туры китерелгән. Постлар чорына туйлар билгеләнмәгән, шуңа күрә алар күбесенчә көзен, Покров постыннан Филипп постына кадәрге чорда (14 октябрьдән 28 ноябрьгә кадәр) уздырылган. Өйләнешү Р.да кодалап һәм туйлап, кайбер очракта ата-ана ризалыгыннан башка («самокрутка») гамәлгә ашырылган. Бала туар алдыннан махсус гореф-гадәтләр һәм йолалар (чистарыну йоласы), бала тугач чукындыру (крестины) башкарылган. Идел буенда яшәгән Р.да җирләү-искә алу ритуалы үлем факты һәм мәрхүмне җирләүгә әзерләү б-н бәйле йола гамәлләреннән, җирләүдән һәм искә алу йолаларыннан гыйбарәт. Р.га зур гаиләле патриархаль традицияләр хас булган. Зур, ягъни бүленмәгән гаилә үзара туры һәм тармак туганлыгы б-н бәйле берничә гаилә парыннан торган, аны бергәләшеп милек биләү, уртак хуҗалык алып бару, уртак торак һәм өстәл берләштергән; гаилә башында өлкән ир торган. Капитализм үсеше патриархаль тормыш тәртибе җимерелүгә, үзара мөнәсәбәтләрнең яңа формалары туугa китерә. Шәһәр һәм сәнәгать үзәкләре йогынтысында авылда җәмгыять һәм гаилә көнкүрешенең яңа сыйфат-














**Руслар**. 1. Крәстиян өе. Биектау районы Кадыш авылы. 20 йөз уртасы фоторәсеме; 2. Туңга сөрү. Казан губернасы Лаеш өязе. 20 йөз башы фоторәсеме; 3. Көндәлек кием кигән крәстиян. Казан губернасы Чабаксар өязе. 20 йөз башы фоторәсеме; 4. Урта Идел буе рус авылында крәстияннәр төркеме; 5. Бәйрәмчә киенгән крәстиян хатын-кыз. Урта Идел буе. 20 йөз уртасы фоторәсеме; 6. Казан хатын-кызлар училищесе укучылары. 20 йөз башы; 7. Алабуга епархия хатын-кызлар училищесе советы әгъзалары. 20 йөз башы фоторәсеме; 8. Казан хәрби училищесенең 4 нче рота курсантлары һәм укытучылары. 1912; 9. Сәүдәгәр Оконишниковлар гаиләсе. 20 йөз башы фоторәсеме; 10. Эшмәкәрләр Н.И. һәм Г.И.Стахеевлар компаньоннары белән. Алабуга шәһәре. 20 йөз башы фоторәсеме; 11. А.Ф.Лихачёв гаиләсе. 1880 еллар фоторәсеме; 12. «Оберег» рус фольклор-этнографик ансамблендә катнашучылар. Казан. 2010.

лары барлыкка килә. Төрле милләт вәкилләре (ш.и. татарлар) б-н янәшә яшәү нәтиҗәсендә Идел буендагы Р. этномәдәни яктан (торактагы җиһазларда, киемдә, ризыкларда һ.б.да) үзгәрешләр кичерәләр, милли составлары буенча катлаулы һәм катнаш җәмәгатьләр оеша, аларда актив рәвештә үзара мәдәни кыйммәтләр, традиция һәм йола элементлары б-н алмашу бара. Идел буенда яшәгән Р.ның йолалар даирәсенә татарларга хас спорт ярышлары, уеннар һәм бәйрәмнәр (*Сабан туе, Җыен* һ.б.) үтеп керә. Р. үз чиратында Татарстанның төп халыклары эшчәнлегенең матди һәм рухи өлкәләренә зур этномәдәни йогынты ясыйлар (к. *Рус алынмалары*). Татарлардан кала Р. — респ-каның иң күп санлы халкы, әмма 1950 еллар ахырыннан авыл җирендә аларның өлеше өзлексез кими бара (к. табл.). Р.ның зур күпчелеге ТР шәһәрләрендә, башлыча, Казанда һәм якын-тирәдәге районнарда, ш.у. Идел, Кама һәм Вятка елгалары үзәннәре тирәсендәге җирләрдә яши. Ш.у.к. *Крәстияннәр*, *Эшчеләр сыйныфы*, *Рус теле*.

Татарстанда 1897–2010 да руслар саны

| Еллар | Сан, кеше | | | |
|---|---|---|---|---|
| | барлык халык | ш.и. руслар | | |
| | | барлык руслар | шәһәрләрдә | авыллларда |
| 1897 | 2170665 | 833340 | 143344 | 689996 |
| 1926 | 2593779 | 1118834 | 204368 | 914466 |
| 1939 | 2915277 | 1250667 | 410844 | 839823 |
| 1959 | 2850417 | 1252413 | 726896 | 525517 |
| 1970 | 3131238 | 1328738 | 934387 | 394351 |
| 1979 | 3445412 | 1516023 | 1216192 | 299831 |
| 1989 | 3641742 | 1575361 | 1349700 | 225661 |
| 2002 | 3779265 | 1492602 | 1287025 | 205577 |
| 2010 | 3786488 | 1501369 | – | – |

Чыг.: Итоги Всесоюзной переписи населения 1926 г. М., 1928. Т. 9; Всесоюзная перепись 1939 г. Основные итоги. М., 1939; Итоги Всесоюзной переписи населения 1959 г. РСФСР. М., 1963; Итоги Всесоюзной переписи населения 1970 г. М., 1973. Т. 4; Итоги Всесоюзной переписи населения 1979. К., 1981. Т. 6; Итоги Всесоюзной переписи населения 1989 г. К., 1990. Т. 2; Основные итоги Всероссийской переписи населения. М., 2005. Т. 4.

*Әд.:* Вопросы формирования русской народности и нации. М.–Л., 1958; Происхождение и этническая история русского народа по антропологическим данным. М., 1965; Русские: Ист.-этногр. атлас. М., 1967; Бусыгин Е.П., Зорин Н.В., Михайличенко Е.В. Общественный и семейный быт русского сельского населения Среднего Поволжья. К., 1973; Бусыгин Е.П., Зорин Н.В. Этнография народов Среднего Поволжья. К., 1984; Бусыгин Е.П., Зорин Н.В., Столярова Г.Р. Этнодемографические процессы в Казанском Поволжье. К., 1991; Русские: Этносоциол. очерки. М., 1992; Русские. М., 1999; Зорин А.Н. Города и посады дореволюционного Поволжья: Ист.-этнограф. исслед. населения и поселенческой структуры городов российской провинции второй пол. XVI – нач. XX вв. К., 2001.

*Р.Р.Батыршин, Г.Р.Столярова.*

**РУСЛАШТЫРУ́ СӘЯСӘТЕ́**, югары хакимиятнең фин-угор, төрки-татар һәм рус булмаган башка халыкларны унификацияләү, этномәдәни ассимиляцияләү сәясәте. Россия тарих фәнендә «Р.с.» төшенчәсенә билгеләмә бирүдә, ш.у. аның иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормыштагы чагылышын бәяләүдә уртак фикер юк. Баштарак, 16–18 йөзләрдә, Россия дәүләтендә Р.с. җәмәгать һәм сәясәт эшлеклеләре тарафыннан «кыргый» һәм «цивилизациядән ерак» рус булмаган халыкларны «югары Европа христиан» мәдәниятенә кушу өчен зарури һәм мәҗбүри чара дип аңлатылган көчләп чукындыру (к. *Христианлаштыру сәясәте*) аша алып барыла. 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында, көчләп христианлаштыру сәясәте йомшара барган саен, Р.с. иҗтимагый үзаң тарафыннан дәүләтнең мәдәни-агарту һәм цивилизацияләштерү сәясәте буларак кабул ителә башлый, шулай да кайбер тарихчылар аның колонизаторлык асылын билгеләп үтә (Н.А.*Фирсов* һ.б.). Көнбатыш историографиясендә Р.с. шәрекъ халыкларына рус мәдәни кыйммәтләрен көчләп тагу итеп карала (К.Маркс һ.б.). 18–19 йөзләр татар иҗтимагый фикере Р.с.нең цивилизацияләштерүдәге әйдәүче ролен битараф кала, милли мәдәниятнең төп элементлары — тел, дин, этник һәм көнкүреш традицияләре һ.б. сакланган хәлдә, үз халкын бөтендөнья мәдәни һәм этносәяси ярыш алгарышына кушу зарурлыгы ассызыклана. 1920 елларда совет җәмгыять белеме фәнендә (М.Н.Покровский, Г.С.*Гобәйдуллин*, Н.Н.*Фирсов* һ.б.) игътибар рус булмаган халыкларга карата патша самодержавиесе үткәргән Р.с.нең бөекдержавачыл һәм көчләүгә корылган асылына юнәлтелә. 1930 еллар уртасыннан тарихчылар һәм сәясәт эшлеклеләренең хезмәтләрендә Р.с.нең яңа (тоталитар) — формасы б-н милли булмаган, ләкин эчтәлеге б-н рус рухындагы идеологиясе формалаша башлый. «Халыклар төрмәсе» булуына карамастан, Россия империясендә «халыкларның якынаюы» кебек прогрессив тенденцияләр күзәтелү билгеләп үтелә, моңа өстәп, рус булмаган халыкларны яктыга алып чыгуда бөек рус мәдәниятенең төп рольне уйнавына басым ясала. Европа колониаль дәүләтләре таркалу чорында Көнбатыш историографиясе Россиянең рус булмаган халыкларга мөнәсәбәттәге бөекдержавачыл сәясәтен, төп игътибарны христианлаштыру һәм Р.с.ндәге «арттырып җибәрүләргә» юнәлтеп, тәнкыйть күзе б-н бәяли башлый (Б.*Шпулер*, А.*Беннигсен*, А.*Каппелер*, Р.Джераси, В.Сандерленд, П.Уэрт, Ю.Слёзкин һ.б.). Татар эмигрантлары даирәсендәге тарихи фикер үсеше ш.у. шушы контекстта бара (Г.*Исхакый*, Г.*Баттал*, Ә.*Курат*, Б.*Иҗболдин*, Т.Дәүләтшин, А.А.*Рорлих* һ.б.). СССР таркалганнан соң (1991), Р.с. историографиясендә берничә юнәлеш барлыкка килә: элекке позициядә калып, держава бөтенлеген саклауга юнәлдерелгән карашлар (Г.А.Зюганов, А.Миграннян һ.б.); Р.с.нең руслар мәнфәгатендә түгел, ә фәкать империяне ныгыту өчен уздырылуын раслаучы империячел карашлар (А.И.Миллер, Б.Н.Миронов, Н.А.Нарочницкая һ.б.); Р.с.нең рус булмаган халыкларның этномәдәни һәм цивилизацияле үсешенә тоткарлык ясавын, күләмле демографик югалтуларга китерүен исбатлаучы карашлар (Р.Г.*Әмирханов*, И.А.*Гыйләҗев*, Ф.Г.Ислаев, Д.М.*Исхаков* һ.б.).

Идел һәм Урал буеның рус булмаган халыкларын руслаштыру тарихы шартлы рәвештә берничә этапка бүлеп карала. 9–13 йөзләрдә Р.с., нигездә, Идел буеның фин-угор халыкларына (*мерәләр, муромлылар* һ.б.) кагыла, руслар тарафыннан *колонияләштерү* барышында алар этномәдәни ассимиляциягә дучар ителә. 13 йөзнең 2 нче — 16 йөзнең 1 нче яртысы арасындагы чорда Алтын Урда дәүләте һәм 15 йөздә ул таркалганнан соң барлыкка килгән *татар ханлыклары* аксөякләреннән бер төркем ш.у. этномәдәни үзгәрешләр кичерә (к. *Йомышлы татарлар*). Рус кенәзләре төрле феодаль өстенлекләр бирү (җир биләмәләре, крепостной крәстияннәр һ.б.) хисабына татар бәкләре һәм морзаларын хезмәткә чакыра, аларның күпчелеге, православие динен кабул итеп һәм ят мәдәни кыйммәтләргә кушылып, рус аристократиясе сафларын тулыландыра (Адашевлар, Апраксиннар, Балакиревлар, Бахметьевлар, Голицыннар, Карандеевлар, Ртищевлар, Сабуровлар, Хитровлар, Языковлар һ.б.). Татар ханлыклары яулап алынганнан соң һәм 16 йөзнең 2 нче яртысында — 18 йөздә Идел һәм Урал буеның руслар тарафыннан колачлы колонияләштерелүе дәвамында Р.с. максатчан рәвештә алып барыла, рус булмаган халыкларны көчләп христианлаштыру һәм унификацияләү башлана. Рус булмаган халыкларны аерым һөнәрләр б-н шөгыльләнүдән тыю (к. *Тыелган товарлар*), аларны җиргә, милеккә ия булудан һәм ш.у. үз катлавы хокукларыннан, төрле өстенлекләрдән (*сөйүргал, тархан* һ.б.) мәхрүм итү аркылы Рус дәүләте Казан җирләренең фин-угор һәм төрки халыклар (нигездә, чуашлар) арасында христиан динен таратуга ирешә. Татар халкының төп өлешенә христианлаштыру турыдан-туры кагылмый, ләкин әлеге сәясәтнең тормышка ашырылуы татар җәмгыятенең тышкы дөньядан аерымлануына һәм цивилизацияле интеграцион бәйләнешләре зәгыйфьләнүгә китерә. Татар бәкләре һәм морзаларының бер өлеше Рус дәүләте хезмәтенә күчә (Державиннар, Карамзиннар, Карамышевлар, Карауловлар, Ханкилдиевләр һ.б.).

Руслаштыруны тизләтү сәясәте — көчләп христианлаштыру (к. *Яңа чукындырылганнар конторасы*) — Идел һәм Урал буенда яшәүче төп халыкларның куәтле кузгалышларын (к. *Казан җирләрендә азатлык сугышлары (1552–56), Казан ханлыгы яулангannan соңгы фетнә-чуалышлар, Башкорт-татар баш күтәрүләре, Батырша хәрәкәте*) китереп чыгара, шул сәбәпле патша хөкүмәте рус булмаган халыкларны яңа мәдәниятккә тартуның цивилизациялерәк юлларына күчәргә мәҗбүр була. Император Екатерина II идарәсе чорында дин ирегә игълан ителә (к. *Синод фәрманы, 1773 ел 17 июнь*). 18 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында Р.с.нең төп күчәре төбәкнең төп халыклары мәгарифе һәм мәдәнияте даирәсенә күчерелә. Р.с. самодержавие, православие, халыкчанлык принципларына нигезләнгән империячел сәясәт кысаларында мәдәни ассимиляцияләү (документ, эш кәгазьләрен рус телендә алып бару, фин-угор һәм төрки халык балалары өчен

мәктәпләр ачу, миссионерлык җәмгыятьләре эшчәнлеге һ.б.); ш.у. башлангыч белем бирү мәктәпләреннән югары уку йортларына кадәрге барлык баскычларны эченә алган гомумроссия мәгарифен унификацияләү аша уздырыла башлый. 19 йөзнең 2 нче яртысында Идел һәм Урал буендагы төп халыкларның (татар, чуаш, мари, удмурт һ.б.) чукындырылган өлеше православиене калдырып күпләп үз диннәренә кайту шартларында Р.с. кискен көчәя, Эчке эшләр һәм Мәгариф министрлыклары эшчәнлегендә этномәдәни басым аеруча нык сизелә. Рус булмаган халыклар өчен рус православие (күпчелеге — миссионерлык) мәктәпләре ачыла, кириллица нигезендә милли алфавитлар булдырыла (к. *Ильминский системасы*), фин-угор һәм төрки халыклар телләренә Инҗил, гыйбадәтнамәләр, догалыклар тәрҗемә ителә (к. *Казан епархиясенең тәрҗемә эшләре комиссиясе*). Мөселман мәктәп һәм мәдрәсәләрендә дөньяви фәннәр һәм рус телен укыту тыела (к. *Александр III Фәрманы, 1888 ел 16 июль*) һ.б. 1870, 1906 һәм 1910 да рус хөкүмәте тарафыннан Россия империясенең рус булмаган халкына аң-белем бирү «кагыйдәләре» эшләнә, төрки халыкларны, аеруча мөселман татарларны бөекдержавачыл рухта мәдәни унификацияләү аерым игътибарга алына (к. *«Идел буе төбәгендә мөселман татарларның йогынтысына каршы чаралар билгеләүче махсус киңәшмә»*).

19–20 йөзләр чигендә идея ягыннан йомылып яшәүче татар җәмгыятендә Р.с. мәсьәләсенә карата фикер каршылыклары сизелә башлый. Җәдитчеләр (к. *Җәдитчелек*) татарларның рус икътисади, этносәяси һәм этномәдәни даирәсенә интеграцияләнүе яклы булса, кадимчеләр (к. *Кадимчелек*) борынгыдан килгән традицион тәртипләрне үзгәрешсез калдырырга һәм сакларга тәкъдим итәләр. Татар дөньяви әдәбияты, яңа — урта гасырлар гарәп һәм фарсы алынмаларыннан арындырылган татар теле, милли вакытлы матбугат, историография туып һәм ныгып килгән әлеге чорда татар җәмгыятенә рус мәдәнияте элементлары, беренче чиратта башка телләрдәге сүз һәм төшенчәләрнең үтеп керүе көчәя. Болар һәммәсе Россиядәге интеграцион бәйләнешләргә тизләнеш бирә һәм татар җәмәгатьчелеген борчуга сала. Татар зыялылары арасында киләчәктә татар халкының юкка чыгу ихтималы хакында кызу бәхәсләр кузгала (Г.Исхакый, «Ике йөз елдан соң инкыйраз», 1904).

Хакимияткә большевиклар килү (1917) һәм элекке Россия империясе терр-ясендә совет хакимияте урнашу б-н, Р.с. яңа этапка аяк баса: сәяси омтылышлар «пролетар интернационализмы» һәм «халыклар дуслыгы» шигарьләре ярдәмендә «милләтләрнең үзара якынаюы һәм мәдәниятләрнең бер-берләренә үтеп керүе»нә юнәлтелә. «Өлкән (рус) туган» җитәкчелегендә уртак социаль-мәдәни һәм этносәяси тарихка ия яңа интернациональ бергәлек — «совет халкы» хасил итү өчен киң колачлы чаралар күрелә башлый (к. *Культура революциясе*). Әлеге сәясәтне тормышка ашыру барышында милли мәдәниятнең роле сизелерлек какшый, туган тел һәм тарих б-н кызыксыну кими, татар җәмгыяте ислам диненнән читләшү, язу үзгәрү (1927–28 дә — *латин язуы*, 1939 да — рус алфавиты кертелү) аша уза. Большевикларның мәдәни сәясәте татар зыялылары вәкилләренә дә кагыла һәм алар арасында фикер каршылыклары китереп чыгара: интернационалистлар татарларны рус телле җәмгыятькә тулысынча тартылырга чакыра, милләтчеләр, татар җәмгыятенең дөнья мәдәнияте, ш.и. рус мәдәнияте казанышларына да таянып, мөстәкыйль этномәдәни үсеш юлыннан баруын зарур саный. Ләкин большевиклардан торган ил җитәкчелеге татар җәмгыятендәге әлеге тенденцияләрне совет хакимиятенә, рев-ция идеалларына, рус милләтенә каршы юнәлтелгән омтылышлар чагылышы дип таба; «буржуаз милләтчеләр», «тайпылучылар», «солтангалиевчеләр»не фаш итү максатыннан, татар сәяси һәм мәдәни элитасы сафлары даими рәвештә «чистарту»ларга дучар ителеп торалар (к. *РКП(б) ҮКның дүртенче киңәшмәсе*). Татарстанда тизләтелгән социаль-икътисади, иҗтимагый-сәяси һәм социомәдәни үзгәртеп корулар чорында татар халкының тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү б-н шөгыльләнүче оешмалар ябыла (к. *Төбәкчелек белеме*), дәүләт аппаратына төбәкнең төп халкы вәкилләрен тарту, дәүләти һәм иҗтимагый оешмаларда татар телен куллануны гамәлгә кертү кискен сүлпәнәя, Р.с.нә каршыларны сәяси фаш итү һәм кыру башлана (к. *Татарстанда 1918–54 еллар репрессияләре*).

1930 еллар ахырында Р.с.нең беркадәр йомшаруы Татарстанда тарих фәнен тергезү мөмкинлеге бирә; ТАССР МС каршында Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты ачылып, анда Татарстан АССР тарихы, татар әдәбияты өйрәнелә башлый, татарча-русча сүзлекләр төзелә, ләкин *«Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»* ВКП(б) ҮК карары (1944) чыкканнан соң, Р.с. кабат көчәя: *Алтын Урда* тарихын, мәдәниятне, милли тарихның кайбер чорларын, ш.и. әдәбият һәм фольклорны (мәс., «*Идегәй*» дастанын) өйрәнү катгый тыела; милли тарих һәм мәдәният эшлеклеләре исемнәренең телгә алынуына цензура кертелә һ.б. Әлеге идеологик басымның нәтиҗәсе буларак, татар халкы этногенезына багышланган *СССР ФА фәнни сессиясендә* (1946 ның 25–26 апреле) татар халкының килеп чыгышына карата аның тарихын һәм мәдәниятен ТАССР кысалары б-н чикләгән болгар теориясе рәсми фараз рәвешендә раслана. Мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен «*монгол-татар изүе*»*нең*, Алтын Урда дәүләтенең, татар ханлыкларының тискәре роленә басым ясалган, СССРның рус булмаган халыклары тарихы һәм мәдәниятенә багышланган мәгълүматлардан мәхрүм дәреслекләр нәшер ителә. Татарстан тарихы буенча «Болгар теориясе»нә нигезләнеп язылган дәреслекләрдә Алтын Урда чоры чагылдырылмый, татар халкының тарихы һәм мәдәниятенә киң колачлы бәя бирелми, христианлаштыру һәм Р.с.нең асылы аңлатылмый, шул ук вакытта рус мәдәниятенең татарларга «прогрессив йогынтысы» аерым билгеләп үтелә, рус хакимияте һәм «милли эксплуататорлар»ның икеләтә изүенә каршы Россия халыклары алып барган бердәм сыйнфый көрәшкә зур әһәмият бирелә. Бу чорда татар теле мәктәпләрдән, балалар бакчаларыннан һәм мәдәни-агарту учреждениеләреннән акрынлап кысрыклап чыгарыла (мәс., 1939/40 уку елында 1732 татар мәктәбе булып, аларда 281 мең укучы, ягъни барлык татар балаларының 49% ы укыса, бу саннар 1959/60 уку елында — 138,5 мең, ягъни 27%, 1980/81 уку елында 104 мең, ягъни 18,6% тәшкил итә). Татар теленең кулланылу даирәсе өй эчендә аралашу дәрәҗәсенә калдырылу аны ана теле санаучы татарлар санының кимүенә алып бара (1926 — 99%, 1959 — 92%, 1970 — 89%, 1989 — 83%). 20 йөзнең 2 нче яртысыннан башлап, Татарстанны һәм өлешчә Башкортстанны санамастан, СССРның татар халкы тупланып яши торган өлкә һәм респ-ка мәктәпләрендә табигыять-техник циклга караган төп фәннәрне укыту татар теленнән рус теленә күчерелә, татар теле һәм әдәбиятын өйрәнүгә билгеләнгән сәгатьләр саны кыскартыла. Күп кенә урыннарда татар интернат-мәктәпләре ябыла, татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләүче курслар бетерелә һ.б. Болар СССР киңлекләрендә яшәүче татар халкының, аеруча аның кечерәк төркемнәренең руслашуына, милли телләрнең сәясәт, мәдәният, әдәбият өлкәсеннән кысрыклап чыгарылуына, катнаш никахлар артуга һ.б.га китерә. Р.с.нең көчәюенә ш.у. тизләтелгән шәһәрләшү процессы (1939 да ТАССР халкының 28% ы, 1959 да — 33%, 1989 да — 42% ы шәһәрләрдә яши), совет режимы шартларында татар җәмгыятендә барган модернизация процесслары (массакүләм мәгълүмат чаралары, эстрада, кинематография һ.б. үсеше), татар халкының традицион тормыш рәвешеннән, ш.и. авыл тормышы тәртипләреннән аерылуы һәм псевдомилли нигездәге, рус мәдәниятенә карата икенчел булган шәһәр мәдәнияте барлыкка килү б-н бәйле үзгәрешләр йогынты ясый.

«Алга киткән социализм» төзү чорында катнаш никахлар советча яңа бергәлек — «совет халкы» барлыкка килү атрибуты булып санала. Бу елларда төрле адм. һәм сәяси-хокукый чаралар ярдәмендә төрле милләт вәкилләре арасындагы никахлар һәм СССР халыкларының «мәдәни якынаюы» хуплана; хезмәт вазифасы буенча күтәргәндә, язылмаган кагыйдәләр хөкем сөрә (партия хезмәткәрләренең, хәрби башлыкларның катнаш никахларына уңай мөнәсәбәт һ.б.). Болар ш.у. татарларның, бигрәк тә яшь буынның турыдан-туры туган телдән читләшүенә, теленең рус алынмалары б-н чуарлануына китерә. Татарстан мәктәпләре укучылары арасында 2005 елда уздырылган сорашу нәтиҗәләре буенча, аларның 10,7% ы — укытучылары б-н, 6% ы — дуслары б-н, 11% ы — күршеләре б-н татарча аралаша, гаиләдә татарча сөйләшүчеләр — 28%. Балаларын рус мәктәпләре һәм балалар бакчаларына биреп, гаиләдә рус телендә аралашуга күчеп, татар

халкы вәкилләре үзләре үк Р.с.н үткәрүчеләр позициясен ныгыталар. Сораштырулардан күренгәнчә, укучы татар балаларының ата-аналары арасыннан 44% ы социаль яктан уңышлы үсеш һәм яхшы эш урынына ия булу өчен рус теле зарур дип саный.

СССР таркалганнан соң (1991), милли респ-каларда мәдәниятләр үсешенә, милли телләрнең кулланылыш даирәсе киңәюгә һ.б.га уңай йогынты ясаган суверенлашу чоры башлана. Җавап йөзеннән үзәк хакимият тарафыннан татар халкы тормышыннан милли-мәдәни кыйммәтләрне, традицияләр һәм гореф-гадәтләрне кысрыклап чыгаруга юнәлтелгән махсус чаралар күрелә. «Россия Федерациясенең кайбер закон актларына (дәүләт мәгариф стандарты төшенчәсен һәм структурасын үзгәртү өлешендә) үзгәрешләр кертү турында»гы 448303–4 номерлы Федераль закон нигезендә «аз комплектлы авыл мәктәпләрен оптимальләштерү», туган телне, милли әдәбият һәм тарихны өйрәнү сәгатьләрен кыскарту, туган телдә укытылучы фәннәр исемлеген чикләү юлы б-н мәгариф сәясәте аркылы этномәдәни ассимиляциягә даими рәвештә көчәйтү буенча максатчан эш алып барыла. Рус телле массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан кешеләр аңына неоимпериалистик штамплар (шулардан бер өлге — «Россия милләте» төшенчәсе) сеңдерү омтылышлары ясала; православиене иҗтимагый тормышның барлык өлкәләренә кертү буенча киң колачлы чаралар үткәрелә. Р.с. татар яшьләрендә этнонигилизм, туган тел, милли мәдәният, тарих, традицияләр һәм гореф-гадәтләр б-н санлашмау, ахыр чиктә этник яктан кимчелек тою китереп чыгара.

*Әд.:* Фирсов Н.А. Инородческое население прежнего Казанского царства в новой России до 1762 года и колонизация заКамских земель в это время. К., 1869; Григорьев А.Н. Христианизация нерусских народностей как один из методов национально-колониальной политики царизма в Татарии // Материалы по истории Татарии. К., 1948; Алишев С.Х. Исторические судьбы народов Среднего Поволжья. XVI — нач. XIX вв. М., 1990; Зюганов Г.А. Россия — родина моя: Идеология государственного патриотизма. М., 1996; Каппелер А. Россия — многонациональная империя: Возникновение. История. Распад. М., 1996; Исхаков И.Д. Проблемы становления и трансформации татарской нации. К., 1997; Миронов Б.Н. Социальная история России периода империи (XVIII — начало XX в.): В 2 т. СПб., 2003; Миллер А.И. Империя Романовых и национализм. М., 2006.

*И.Л.Измайлов, Р.В.Шәйдуллин.*

**РУС-МАРИ́ КАВАЛЫ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 42 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Солонка елгасы буенда. 2010 елда 56 кеше (марилар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Чиркәү. 1615 тән Кавал авылы буларак билгеле. 1928 гә кадәр Рус-Чирмеш Кавалы исеме б-н мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, такта яру, тегүчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, земство мәктәбе (1873 тә ачыла), 3 тегермән, 2 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1696,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кавал волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 92 ир-ат; 1859 да — 575, 1897 дә — 751, 1908 дә — 832, 1920 дә — 731, 1926 да — 885, 1938 дә — 632, 1949 да — 400, 1958 дә — 541, 1970 тә — 362, 1979 да — 237, 1989 да — 131, 2002 дә — 102 кеше.

**РУС-МАРИ́ КАВАЛЫ́ КҮЛЕ́** (Озынбы), Көнбатыш Кама алдында, Солонка, Сумка һәм Питиал елгалары бассейнарының субүләрендә урнашкан, Яшел Үзән р-ның Рус-Мари Кавалы авылыннан 1,5 *км* төньяк-көнбатыштарак. Су өслегенең мәйданы 7,9 *га*. Су күләме якынча 400 мең $м^3$.



Рус-Мари Кавалы күле.

Озынлыгы 600 *м*, иң зур киңлеге 180 *м*. Уртача тирәнлеге якынча 6 *м*, иң зур тирәнлеге 20 *м*. Күл карст-суффозия процессы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы озынча, борылмалы. Ярлары тәбәнәк, куаклар б-н капланган. Туенуы катнаш, атм. явым-төшемнәре һәм грунт сулары исәбенә. Суы үтә күренмәле (230 *см* га кадәр), бик йомшак, гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта. Гомуми минеральләшүе 317 *мг/л*. Ял итү урыны. ТРның табигать истәлеге (1978).

**РУ́ССКИН** Степан Васильевич (5.5.1933, Мордва авт. өлкәсенең Дубёнск р-ны Чиндяново а. — 18.6.2005, Яшел Үзән ш.), конструктор, СССР Дәүләт бүләге иясе (1985). 1970 елда Горький су транспорты инженерлары ин-тын тәмамлый. 1952 дән Яшел Үзәннең А.М. Горький исем. з-дында, 1958 дән Яшел Үзән проектлау-конструкторлык бюросында, баш конструктор урынбасары (1975–95). Дәүләт бүләге суднолар төзү өлкәсендә яңа техника булдырганы өчен бирелә. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар. Медальләр, «СССРның уйлап табучысы» билгесе б-н бүләкләнә.

**РУС-ТАТА́Р ӘЙШЕСЕ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 22 *км* төньяктарак, Шуман елгасы буенда. 2010 елда 31 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Рус Әйшесе (18 йөзнең 2 нче яртысында нигезләнә) һәм Татар Әйшесе (Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм) авыллары кушылу нәтиҗәсендә 1991 дә барлыкка килә. 1861 елгы реформага кадәр Рус Әйшесе халкы — алпавыт, Татар Әйшесе халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, йон-тукыма ману, он тарту, прәннек пешерү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Рус Әйшесендә 2 җил тегермәне, ярма яргыч, тимерчелек, 2 мануфактура һәм 1 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 518,1 (Татар Әйшесендә — 227,7) дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр ике авыл да Казан губернасының Казан өязе Чыпчык волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Татар Әйшесендә халык саны: 1782 дә — 148 ир-ат; 1859 да — 144 (Рус Әйшәсендә — 364), 1897 дә — 155 (344), 1908 дә — 119 (293), 1920 дә — 121 (286), 1926 да — 123 (367), 1949 да — 592 (152), 1958 дә — 473 (63), 1989 да — 71, 2002 дә — 46 кеше.

**РУС-ТАТА́Р УЧИ́ЛИЩЕЛӘРЕ**, татар балалары өчен башлангыч уку йорты. Россиядә яшәүче башка милләт кешеләренә белем бирү чаралары турындагы 1870 елның 26 март кагыйдәләре буенча, Казан һәм Симферополь шәһәрләрендә татар укытучылар мәктәпләре турындагы 1872 нең 27 март нигезләмәсе, Россиянең көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгышында яшәүче башка милләт кешеләре өчен башлангыч уч-щеләр турындагы 1907 нең 1 ноябрь карары буенча эшлиләр. Укытучылар Казан һәм Уфа татар укытучылар мәктәпләрендә әзерләнә. Уч-щеләрнең күпчелеге земство һәм шәһәр үзидарә органнары тарафыннан, кайберләре Халык Мәгарифе министрлыгы хисабына финанслана. Р.-т.у. Казандагы ятим балалар йортларында да — Юнысовлар ятимханәсендә һәм Фәкыйрь мөселманнарга ярдәм җәмгыятендә эшли. Уку срогы — 3 ел, рус теле бердәнбер фән була; арифметика, тел белеме, табигать фәннәре буенча белешмәләр уку китабында бирелә. Ислам динен чакырылган муллалар укыта, аларга эш хакын земство һәм шәһәр үзидарә органнары түли.

Беренче Р.-т.у. Казанда, Оренбургта, Уфада 1875 тә барлыкка килә. 1905 кә кадәр аларга татар җәмәгатьчелеге ышанып бетми. Кадимче муллалар һәм крәстияннәрнең шактый өлеше бу уч-щеләр миссионерлык максатларында оештырылган һәм алга таба гомуми христианлаштыру булачак дип куркалар. Җәдитчеләрне Р.-т.у.нең хөкүмәт күзәтүе астында булуы һәм татар теле укытылмау канәгатьләндерми. Р.-т.у.нең барлыкка килүе җәдитчелек таралуга ярдәм итә, сыйныф-дәрес системасының, укырга-язарга өйрәтүдә авазлар алымының, чит телне өйрәнгәндә заманча методиканың нәтиҗәлелеген күрсәтә. 1905 елга Казан уку-укыту округында 31 Р.-т.у. эшли (ш.и. Казанда — 5, Сембер, Чистай, Тәтеш, Мамадыш, Буа, Малмыжда берәр була), Оренбург уку-укыту округында — якынча 30, калган округларда якынча 20 уч-ще (Түбән Новгород, Пенза, Рязань губерналарында) була. 1905–07 елгы рев-циядән соң Р.-т.у. челтәре татар җәмәгатьчелегендә ышаныч арту аркасында үсеш ала. 1917 гә Казан гу-

бернасында гына да алар 100 дән артык була. Казан губерна земствосы гомуми башлангыч белем бирү планнары буенча барлык татар авылларында — Р.-т.у., укытучылар әзерләү өчен тагын 3–4 татар укытучылар мәктәбе ачуны планлаштыра. Бу планнарны тормышка ашыруга Беренче бөтендөнья сугышы комачаулый. 1918 дә уч-щеләрнең күбесе ябыла, кайберләре совет башлангыч мәктәбе итеп үзгәртелә. Р.-т.у.ндә күп кенә атаклы педагоглар, тел белгечләре, җәмәгать эшлеклеләре эшчәнлекләрен башлыйлар: Г.Н.Әхмәров, Г.Х.Еникиев, И.М.Казаков, Г.Ю.Коләхмәтов, М.Х.Корбангалиев, Н.К.Мөхетдинов, М.Г.Мөштәри, Н.С.Надиев, Г.В.Рәфыйков, З.С.Рәхмәтуллин, Г.Ш.Сәйфуллин, М.А.Фазлуллин.

*Әд.:* Махмутова А.Х. Становление светского образования у татар (Борьба вокруг школьного вопроса, 1861–1917). К., 1982.

**РУСТИ́ЦКИЙ** Осип Александрович (4.4.1839, Херсон ш. — 13.4.1912, Киев), хирург, медицина д-ры (1870). Киев ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1861), шунда ук өяз табибе вазифасында калдырыла, 1864–68 елларда факультет хирургия клиникасы директоры ярдәмчесе. 1868–74 тә Европа клиникаларында стажировка уза. Франция-Пруссия сугышында катнаша (1870–71). 1874 тә — Александр исем. хастаханә (С.-Петербург), 1886 дан Киев шәһәр хастаханәсе ординаторы. 1893–97 дә Казан ун-тының оператив хирургия каф. мөдире, 1897 дән ординар проф. 1898–1912 дә Киев ун-тында. Хезмәтләре офтальмологиягә, оператив хирургиягә карый.

Х е з м.: К учению о заживлении ран роговицы. Киев, 1870; Исследование о нагноении кости // Мед. вестн. 1872. № 4–5; К вопросу о лечении грыж // Врач. 1890. № 34–36; Краткий исторический очерк развития хирургии // Уч. зап. Казан. ун-та. 1894. Т. 61, кн. 1.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; О.А.Рустицкий: Некролог // Ист. вестн. 1912. Т. 128, № 6; Казанский государственный медицинский университет (1804–2004) гг.): Биогр. словарь. К., 2004.

**«РУС-ФРАНЦУ́З СУГЫШЫ́ БӘЕТЕ́»**, хәрби-тарихи татар *бәете*. 1812 елгы Ватан сугышы вакыйгаларын — Наполеон гаскәрләренең Мәскәүне алуын һәм аннан качуын, татарлар (типтәрләр) һәм башкортларның илбасарларга каршы көрәштә катнашуларын чагылдыра: «Мәскәүгә дә кердек без, Наполеонны күрдек без, / Французны җиңгәндә җир җимереп йөрдек без. / Французны кудык без, үз иленә сөрдек без, / Французларны куганда күп суларны йөздек без».

Эчтәлеге һәм идея юнәлеше ягыннан охшаш, әмма строфаларның саны һәм урнашуы б-н аерылып торган берничә варианты бар. Беренче тапкыр Н.Ф.Катанов Казанда 1899 да «Казан татарларының тарихи җырлары» китабында бастыра (сүзләре татар телендә, транскрипциясе һәм русчага тәрҗемәсе бирелә). Бәетнең берничә дистә варианты 20 йөз башы – 20 йөз уртасында Татарстанның һәм Пенза өлкәсенең төрле районнарында халыктан язып алына; 1905 елгы кульязма исемлекләр буенча 10 га якыны яңадан тергезелә (ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының фольклор фондында саклана).

*Әд.:* Б ә д и г ы й Х. Бәетләр. К., 1913; Татар халык иҗаты: Бәетләр. К., 1983; У р м а н ч е е в Ф. Лиро-эпос татар Среднего Поволжья. К., 2002.

*Ф.И.Урманчеев.*

**«РУСЬ ПРАВОСЛА́ВНАЯ И САМОДЕРЖА́ВНАЯ»** («Православиеле һәм самодержавиеле Русь»), атналык иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. «Рус җыены»ның һәм *Казан аеклар җәмгыятенең* Казан бүлеге органы. 1905 елның июненнән 1915 нең сентябренә кадәр (аерым саннары 1916 да басыла дип фаразлана) Казанда рус телендә нәшер ителә. Бүленеп басыла. 1905 нең июненнән 14 октябренә кадәр — 20 саны чыга, басмаханә эшчеләренең баш күтәрүләре һәм җирле нәшрият хуҗаларының заказларны башкарудан баш тартуы сәбәпле, чыгудан туктап тора; 1907 дә кабат басыла башлый; 1915 нең сентябрендә сугыш чоры авырлыклары аркасында тагын чыгудан туктый. Нашире һәм мөхәррире — «Рус җыены»ның һәм Казан аеклар җәмгыятенең Казан бүлеге рәисе А.Т.*Соловьёв*. «*Деятель*» ж-лына кушымта буларак таратыла (1905 тә журнал әбүнәчеләренә бушлай җибәрелә, аннары язылучыларга таратыла). Газета консерватив карагруһ-монархик юнәлештә була, рев-циягә һәм либераль реформаларга каршы актив чыгыш ясый, «аек» карашлыларны пропагандалый. Даими сәхифәләре һәм авторлары булмый. Язмаларның күп өлеше башкала һәм провинциаль уң монархик («Земщина», «Мирный труд», «Московские ведомости», «Русское знамя» һ.б.) һәм «аек» басмаларның язмаларын кабат бастыру юлы б-н дөнья күрә. Газетада манифестлар, рескриптлар, патша Николай II нең чыгышлары, «Рус халкы берлеге» («Союз русского народа») Баш советы һәм аның рәисе А.И.Дубровинның мөрәҗәгатьләре, Дәүләт Думасына сайлаулар б-н бәйле мөрәҗәгатьләр, уң депутатларның чыгышлары, җыелышлар беркетмәләре, уң монархик һәм «аеклар» җәмгыятьләренең утырышлары, съездлары һәм акцияләре турындагы игъланнар һәм репортажлар басыла. Чиркәү иерархлары һәм билгеле православие эшлеклеләре, ш.и. протоиерей И.И.Сергиев (Кронштадтский), епископлар Андрей (кенәз А.А.Ухтомский), Антоний (А.П.Храповицкий), Никон (Н.И.Рождественский) һ.б.ның дини һәм иҗтимагый тормышындагы вакыйгалар б-н бәйле рәвештә, дин тотучы халыкка мөрәҗәгать б-н чыккан язмаларга зур игътибар бирелә. Мәктәпкә, милли һәм дини мәсьәләләргә кагылышлы, «яһүд йогынтысы»на, «раскольникларга» (иске дин тарафдарлары) һәм «мөхәммәди берлекләр»гә каршы юнәлдерелгән язмаларга, эчүчелек, тәмәке тарту, хулиганлыкка каршы көрәшкә багышланган мәкаләләргә, патриотик эчтәлектәге шигырьләргә зур урын бирелә.

*Әд.:* А л е к с е е в И.Е. Русское национальное движение в Казанской губернии и Татарстане: конец XIX — начало XX веков. К., 2004.

*И.Е.Алексеев.*

**«РУС-ЯПО́Н СУГЫШЫ́ БӘЕТЛӘРЕ́»**, 1904–05 елгы рус-япон сугышы турында хәрби-тарихи татар җырлары циклы. Һәрберсе аерым сәнгать әсәре булган һәм аерым бер темага багышланган 11 бәеттән тора. Бәетләр герой-солдат исеменнән сөйләнә. Цикл туган якларыннан сугышка китеп баручы, яңа гына хезмәткә алынган солдатларның хәсрәт-сагышлары турындагы бәеттән башланып китә. Аннан соңгы бәетләрдә рус гаскәрләренең Кореяга килүе, хәрби хәрәкәтләр башлану, Порт-Артурга һөҗүм итү, Харбин өчен сугышлар һәм сугышның башка вакыйгалары тасвирлана. Лирик герой-солдат хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга соклана, һәлак булуларына кайгыра, командирларның солдатларга карата тупас мөгамәләсе аның ачуын китерә.

«Р.-я.с.б.» кульязма вариантларда киң таралганнар. Беренче тапкыр «Сугыш бәете» (1905) җыентыгында басылалар. Бөек Ватан сугышы елларында бик популяр булалар. «Татар халык иҗаты: Бәетләр» (1983) җыентыгына аларның шактый өлеше кергән. «Р.-я.с.б.» циклы бәетләренең 15 варианты ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты фольклор һәм фәнни фондларында, Казан ун-ты Фәнни китапханәсенең кульязмалар бүлегендә саклана. Бәетләрне Х.Бәдигый, Х.Х.Ярми һ.б. фольклорчылар өйрәнә.

*Әд.:* У р м а н ч е е в Ф. Лиро-эпос татар Среднего Поволжья. К., 2002.

*Ф.И.Урманчеев.*

**РУТЕ́НИЙ** (Ruthenium), Ru, Д.И.Менделеевның элементларның периодик системасында VIII группадагы химик элемент, атом номеры 44, атом массасы 101,07; платина металларының берсе. 1844 елда Казан ун-тында К.К.*Клаус* тарафыннан ачыла, исеме Россия хөрмәтенә (соңгы чор латин телендә Ruthenia — Россия) бирелә. Табигатьтә масса саны 96, 98–102, 104 булган тотрыклы 7 изотобы бар. Массасы буенча Җир кабыгының $5 \cdot 10^{-7}$% ын тәшкил итә. Минераллары — рутенийлы сысерскит (Os, Ir, Ru), рутенийлы невьянскит (Ir, Os, Ru), ауросмирит (Ir, Os, Au), осрутин (Ru, Os); изоморф катышма буларак саф $P_t$ һәм бакыр-никельле мәгъдән минералларына керә. Төш реакторларында уран бүленгәндә, шактый микъдарда Р. хасил була. Р. — көмешсыман ялтыравыклы, соргылт төсмерле уалучан металл, тыгызлыгы 12,37 $г/см^3$, эрү темп-ратурасы 2250 °С, кайнау темп-расы 4200 °С. Компактлы Р. кислоталарга (патша аракысына — 100 °С ка кадәр, $H_2SO_4$ кә 300 °С ка җылытканда да тотрыклы кала) һәм селтеләргә тотрыклы; порошоксыман халәттә NaClO эремәләре, пероксидлар эретмәләре б-н тәэсир итешә. Комплекслы кушылмалар хасил итә. Р. табу чыганаклары — платиналы металлар эшкәртүдән калган ярымпродуктлар, никель җитештерү шламнарын эшкәртүдән калган рутенийлы калдыклар. Р. коелмаларының төп үзлекләре — аларның катылыгы һәм чыдамлыгы.

44 **Ru**
1 15 18 8 2 $4d^7 5s^1$ 101,07±2
РУТЕНИЙ

Саклагыч катламнар (электр контактлары, титан электродлар), декоратив капламнар (ювелир эшләнмәләр) ясауда, фарфор өчен буяулар әзерләүдә, кайбер органик реакцияләрдә катализатор сыйфатында кулланыла.

*Әд.:* Краткая химическая энциклопедия. М., 1965. Т. 4; Химия: Большой энцикл. словарь. М., 2000.

**РУФИ́МСКИЙ** Николай Петрович (4.12.1888 — 1936), ветеринар-микробиолог, вет. фән. д-ры (1926), проф. (1930). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1913). 1913–21 елларда вет. табибе булып эшли. 1922–30 да Мәскәү вет. ин-тында: укытучы, доцент, проф., микробиол. каф. мөдире. 1930–36 да Казан вет. ин-тының микробиол. каф. мөдире. Фәнни эзләнүләренең төп юнәлешләре — бал кортлары авыруларын, бруцеллёз, атлар энцифаломиелитын, а.х. терлекләренең продуктлылыгын арттыру максатыннан, йогышлы авыру барышында, гистолизатлар куллануны өйрәнү. Бруцеллёзны аллергик диагнозлау өчен — бруцеллин, йогышлы авырудан — вакцина, кроликларны томаудан, дуңгыз балаларын үпкә ялкынсынуыннан дәвалау өчен лизатлар уйлап таба.

Х е з м.: К вопросу агглютинации сперматозоидов в нормальной и специфической сыворотке // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1926. Т. 37, вып. 1; К вопросу этиологии европейского гнильца // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1937. Т. 37, вып. 2.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*Р.Г.Госманов.*

**«РУХИЯ́Т»**, шул исемдәге рухи яңарыш фонды нәшрияты. 1997 елда оеша. Оештыручылары — «Татнефть» АҖ, «Татех» АҖ һәм «Татойлгаз» АҖләре, «Девон-кредит», «Зенит» банклары, «Чулпан» иминиятләштерү компаниясе. Татарлар һәм ТРның башка халыклары тарихы, мәдәнияте һәм рухи тормышына багышланган китап продукциясен бастыра. 2014 нең ахырына якынча 170 исемдәге китап, ш.и. ТР ФА Тарих ин-тының РФ фәнни учреждениеләре һәм әйдәп баручы галимнәре б-н берлектә әзерләнгән «Татар халкы тарихы»ның («История татарского народа с древнейших времён») беренче 2 томы; Р.*Фәхретдиннең* тарихи тупланмалары; татар мәгърифәте һәм мәдәнияте эшлеклеләренең биографияләре — «Шиһабетдин Мәрҗани» (1998), «Ризаэтдин Фәхретдин: Фәнни-биографик җыентык» («Ризаэтдин Фахретдинов: Научно-биографический сборник», 1999), «Бертуган Бубилар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе: Тарихи-документаль җыентык» (1999), «Фатих Кәрими: Фәнни-биографик җыентык» («Фатих Карими: Научно-биографический сборник», 2000), «Газиз Гобәйдуллин: Фәнни-биографик җыентык» (2002), «Бертуган Рәмиевләр: Фәнни-биографик җыентык» (2002), «Бертуган Туйкиннар: Тарихи-документаль җыентык» (2007) һ.б. басылып чыга. Язучы Г.Гыйльманов, Х.Камалов, Р.Кәрами, М.Маликова, Ф.Садриев, Ф.Яруллин, М.Юныс әсәрләре басыла. Татар һәм рус телләрендә М.Әгъләмов, Г.Афзал, Н.Әхмәдиев, Роберт Әхмәтҗанов, Рәшит Әхмәтҗанов, К.Булатова, Р.Гатауллин, Н.Гамбәр, Ф.Гыйззәтуллина, Зөлфәт, Ә.Маликов, Р.Миңнуллин, Гәрәй Рәхим, С.Сөләйманова, А.Хәлим, Э.Шәрифуллина, яшь шагыйрьләрнең 20 дән артык шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Татарстан чишмәләре, ат спорты, нефть сәнәгате тарихына багышланган фотоальбомнар әзерләнә. Рәссам Ә.Фәтхетдинов, М.Хәйретдинов тормышы һәм иҗатына багышланган альбомнар чыгарыла. Продукциянең күп өлеше ТР китапханәләренә тапшырыла.

**РУХЛЯ́ДЕВ** Николай Петрович (15.4.1869, Вятка губ. Көлмез а. — 11.10.1942, Казан), ветеринар-гематолог, вет. фән. д-ры (1934), проф. (1917), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1933, 1940). Вет. терапевтлары һәм диагностларының Казан мәктәбен оештыручы. Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1895), шунда эшкә калдырыла, 1922–42 елларда терапия каф. мөдире. Хайваннардан сөяк мие пунктаты алу һәм аны өйрәнү ысулларын эшли, авыру терлекләрне җентекле клиник өйрәнү кан һәм бәвел анализлары нәтиҗәләренә карап алып барылырга тиешлеген нигезли. Йорт хайваннары кан күзәнәкләренең уникаль гематологик атласын төзи (1939). 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Материалы к клиническому диагнозу и патологической гистологии острого нефрита лошади и собаки. К., 1902; Результаты микроскопического исследования молозива и вымени коров при родильном парезе // Уч. зап. Казанского вет. ин-та. 1906. Т. 23.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*Г.А.Пахомов.*

**РУШ** Генрих (Генрих-Якоб) Бернгардович (1855 — 22.8.1905, Казан), архитектор. 1871 елда Сәнгать академиясен тәмамлый. 1880 нән Казан шәһәр идарәсендә, 1884 тән шәһәр архитекторы. 1887 дә эшеннән китә, шәхси эшчәнлек алып бара. Казандагы күп кенә җәмәгать һәм торак биналары проектларының авторы. Арада аеруча билгеле корылмалар: *Александровлар пассажы* (1884–86), Иоанн-Предтеча монастыре (1888), хәрби госпитальнең яңа бинасы (1891–92), вет. ин-ты бинасы комплексы (1896–98), *Чернояров пассажы* (1901), *Шамил йорты* (1903, Ф.Р.Амлонг б-н бергә), *Кекин йорты* (1903–05). Эклектика стиленең төрле юнәлешләрендә эшли; Р. корылмалары декоратив детальләргә бай. Илл.не *Александровлар пассажы, Кекин йорты, Чернояров пассажы, Шамил йорты* мәкаләләреннән кара.

*Әд.:* О с т р о у м о в В.П. Казань. Очерки по истории города и его архитектуры. К., 1978; М у р т а з и н а Л.М. Архитекторы Казани XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999.

**РФ**, к. *Россия Федерациясе.*

**РФ ЭЧКЕ́ ЭШЛӘ́Р МИНИ́СТРЛЫГЫНЫҢ КАЗА́Н ЮРИ́ДИК ИНСТИТУТЫ́**, 1974 елда СССР Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Читтән торып белем бирү юридик ин-ты Мәскәү ф-лының Казан уку-укыту-консультация пункты (КУП) буларак ачыла, 1999 дан хәзерге исемендә. Бюджет нигезендә хокук саклау органнары өчен кадрлар әзерләү (курсантлар), «юриспруденция» белгечлеге буенча укыту (студентлар), Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү б-н шөгыльләнә. Институт составында читтән торып укыту, һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү, бюджеттан тыш юридик (көндезге бүлектәге курсантларны укыту факультеттан тыш алып барыла) ф-тлар эшли; 14 кафедра, 16 лаборатория, криминалистика полигоны бар. 2015 елга — көндезге бүлектә якынча 424 курсант һәм читтән торып уку бүлегендә якынча 1209 студент. Пед. коллективта 130 кеше эшли, ш.и. 20 фән. д-ры, 93 фән. канд. (килеп эшләүчеләрне дә кертеп). 2003 тән адъюнктура эшли. Нәшрият, эчке эшләр органнары һәм югары уку йортының тарих музее. Институтта якынча 4 мең белгеч әзерләнә. Институтны тәмамлаучылар арасында — ТР эчке эшләр министры, РФ эчке эшләр министрлыгының төп мәгълүмат үзәге башлыгы И.Г.Галимов, ТР эчке эшләр министры урынбасарлары Р.З.Тимерҗанов, Р.Г.Ногманов, Казан юридик ин-ты башлыгы Н.Х.Сафиуллин. Институт башлыклары — Г.С.Елманов (1974–78), С.Ж.Япиев (1978–84), Р.Ш.Мигунов (1984–93), Н.Х.Сафиуллин (1993–2008), Ф.К.Зиннуров (2008 дән).

*А.Р.Шамигулов.*

**РФА КГҮ**, к. *Россия Фәннәр академиясенең Казан гыйльми үзәге.*

**РФА КГҮнең ФӘННИ́ КИТАПХАНӘСЕ́**, к. *Россия Фәннәр академиясе Казан гыйльми үзәгенең фәнни китапханәсе.*

**РЫБАКО́В** Сергей Гаврилович (27.9.1867, Самара ш. — 28.12.1921, Рига ш.), музыка белгече, фольклорчы, этнограф. Петербург ун-тының тарих-филол. ф-тын (1889), Петербург консерваториясен композиция теориясе буенча (Н.А.Римский-Корсаков классы) тәмамлый. 1893 елдан Рус геогр. җәмгыяте хезмәткәре, 1913–17 дә — Эчке эшләр министрлыгында Чит илләрнең рухият эшчәнлекләре буенча департаментында, 1917 дә Вакытлы хөкүмәтнең Дини эшләр министрлыгында эксперт-референт. 1893, 1896, 1897 дә, муз. фольклор материаллары җыю өчен, Урал якларына экспедициягә чыга; хезмәтләрен «Урал мөселманнарының көнкүреш тарихы белән музыкасы һәм җырлары» («Музыка и песни уральских мусульман с очерком их быта», СПб., 1897) китабында бастыра. Анда Оренбург губернасының Уфа, Троицк, Югары Урал һәм Орск өязләрендә язып алынган 204 башкорт һәм 54 татар (ш.и. 7 се типтәр, 2 се нагайбәк) җырының ноталары, текст һәм тәрҗемәләре урын алган.

Ә с ә р.: 50 песен татар и башкир с текстами, переводами и гармонизацией. М., 1922.

*Әд.:* А т а н о в а Л.П. Собиратели и исследователи башкирского музыкального фольклора. Уфа, 1992; А р а п о в Д.Ю., Л а р и н а Е.И. С.Г.Рыбаков и его «обзор» организации духовной жизни мусульман России (апрель 1917 г.). М., 2006.

**РЫ́БУШКИН** Михаил Самсонович (1792, Сембер (хәзер Ульянов) ш. — 20.3.1849, Казан), тарихчы, журналист. 1801–10 елларда Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә, 1810–12 дә Казан ун-тының тел һәм әдәбият белеме бүлегендә укый. 1812 дән Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә

тел, әдәбият, тарих һәм геогр. укыта, 1826–28 дә Казан губернасында уч-щеләр директоры; бер үк вакытта, 1823–35 тә, Казан ун-тының рус теле һәм әдәбияты адъюнкты, 1830–32 дә ун-т басмаханәсе идарәчесе. Р.да тел һәм әдәбиятка кызыксыну уятучы гимназия укытучылары арасында шагыйрь Н.М.*Ибраһимов* та була. Р.ның беренче шигырь һәм мәсәлләре 1812 дә студентларның «Смесь» кулъязма ж-лында нәшер ителә. 1814 тә Мәскәүдә «Иоанн, яки Казанны алу» («Иоанн, или Взятие Казани») трагедиясе нәшер ителә. Явыз Иван патша, аның тарафдарлары А.Адашев һәм А.Курбский, Сөембикә ханбикә, Шаһгали хан — трагедиядә катнашучы төп шәхесләр. Әсәр уңышсыз була, яшь Пушкин бу уңайдан «Рыбушкинга» («На Рыбушкина», 1815) эпиграммасын яза. «Тәнкыйтьнең файдасы һәм җайсызлыгы турында» («О выгодах и неудобствах критики»), «Рим әдәбияты турында бернәрсә» («Нечто о римской литературе»), «Лирик поэзия турында» («О лирической поэзии») фәнни мәкаләләре «Казанский вестник» ж-лында басыла. 1823 тән Р. — әлеге журналның редколлегия әгъзасы. 1828 дә аңа «Прибавления к Казанскому вестнику» г-тасын чыгару йөкләнә. 1833 кә, газетаның ябылуына кадәр, Р. аның мөхәррире була. 1832–34 тә Казан ун-ты адъюнкты М.В.Полиновский б-н берлектә Казандагы беренче хосусый журнал — «*Заволжский муравей*»ны нәшер итә. Журнал төбәк тормышында әһәмиятле күренеш була, анда Р. Болгар, Биләр, Иске Казанга барып кайткач туплаган материалларын бастыра. Казан тарихына багышланган мәкаләләрнең күбесе «Казан шәһәренең кыскача тарихы» («Краткая история города Казани», 1834) китабы нигезенә ята. Аны әзерләгәндә П.И.Рычков, А.И.Лызлов, К.Ф.Фукс хезмәтләре, патриарх Гермоген кулъязмасы (1592), Казан епархиясе, Адмиралтейство конторасы, Казан ун-ты, гимназия документлары, Ю. фон Каница картасы файдаланыла. «Шәһәрдә яшәүчеләрнең йолалары һәм гореф-гадәтләре» («Нравы и обычаи жителей»), «Татарларда мәгариф турында» («Об образовании между татарами»), «Татар бәйрәмнәре турында» («О праздниках татарских») исемле бүлекләрендә татарларның дини тормышы, уку-укытуның торышы, Сабан туе, Рамазан, Корбан бәйрәме һ.б. турында бәян ителә; китап ахырында Казан ханнары, воеводалар, губернаторларның исемлеге бирелә. Китап — Казан тарихына багышланган комплекслы хезмәт. Анда шәһәрнең үткәндәге һәм хәзерге торышы тасвирлана, тарихи фактлар, статистика, көнкүреш һәм этнографик күзәтүләр урын ала (1834 тә Р. китапны А.С.Пушкинга җибәрә, 1835 тә Пушкин аңа «Пугачёв фетнәсе»нең («Пугачёвский бунт») бер нөсхәсен бүләк итә). 1835 тән Әстерхан губернасы уч-щеләре директоры. Р. вакытында Әстерхан гимназиясендә татар укучыларының саны арта, гарәп теле укытыла башлый, иң яхшы укучылар Казан ун-тына укырга керә. 1839 да «Әстерхан губернасын статистик һәм топографик яктан тасвирлау» («Статистическое и топографическое описание Астраханской губернии», нәшер ителми) китабын язып тәмамлый. 1841 дә Мәскәүдә, төбәк тарихының төп баскычлары чагылган «Әстерхан турында язмалар» («Записки об Астрахани») басыла (бүлекләре — «Әстерханның башлануы турында» («О начале Астрахани»), «Әстерханны буйсындыру» («Покорение Астрахани»), «Разинның явызлыклары һәм Әстерханга килгән афәтләр» («Злодействия Разина и бедствия Астрахани»), «Пугачёв» һ.б.); тарихи өлеше кәсепчелек, сәүдә, балык тоту турында мәгълүмат тупланган документлар б-н тулыландырыла; татар халкы кыскача тасвирлана (җирле йорт татарлары, Казан татарлары аерып чыгарыла), татарларның саны (10 мең кеше), Әстерхан татарларының урнашуы һәм аларның төп шөгыльләре турында мәгълүмат бирелә. 1843–46 да Пенза губернасы уч-щеләре директоры. 1843 тә нәселдән күчмә дворянлык дәрәҗәсе бирелә. 1846 да отставкага чыга, Казанда яши. 1848–49 да «Казан шәһәренең кыскача тарихы»ның тулыландырылган 2 нче басмасын 2 өлештә чыгара. Р. үзенең хезмәтләрендә «һәр төбәк, шәһәр һәм урынның тарихы дәүләт тарихының бер буыны» булуын ассызыклый.

*Әд.:* А р и с т о в В.В., Е р м о л а е в а Н.В. Всё началось с путеводителя... К., 1975; А л и ш е в С.Х. По следам минувшего. К., 1986.

*Р.А.Айнетдинов.*

**РЫ́ЖИХ** Александр Фёдорович (5.11.1913, Курск губ., хәзер Белгород өлкәсе Губкин р-ны Коньшино а. — 1997, Казан), ветеринар-анатом, гистолог, биол. фән. д-ры (1966), проф. (1967). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1939), анатомия кафедрасында эшкә калдырыла, 1967–88 елларда гистология каф. мөдире. Фәнни эзләнүләренең төп юнәлеше — организмның биоморфологик закончалыкларын онтогенезда — яралу мәленнән алып, табигый үлеме б-н тәмамланган үсеше чорында өйрәнү. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К вопросу об иннервации коленного сустава лошади // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1952. Т. 59; Предпосылки к созданию единой теории структурной организации нервной системы животных // Вопросы морфологии нервной системы животных. Ульяновск, 1976.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**РЫ́ЖКИНА** Ирина Сергеевна (14.2.1953, Казан), физик-химик, химия фән. д-ры (2005). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1975), РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2008 дән). Хезмәтләре супрамолекуляр химиягә карый. Р. ортоаминометилфеноллар һәм аларның комплексларының үзлекләрен һәм бакыр (II) б-н реакциягә сәләтен, актив өслекле матдәләрнең мицелляр эремәләренең аларның каталитик активлыгына тәэсирен тикшерә. Өслекчә активлыгы югары, фосфор к-тасы эфирларына карата солюбилциягә (билгеле бер тирәлектә эретергә) сәләтле һәм компонентлар концентрациясе түбән шартларда да каталитик активлыкка ия булган амфифил каликсареннар нигезендә супрамолекуляр наносистемалар булдыруның принципларын эшләүдә катнаша. Амфифил каликсареннарның сулы һәм сусыз тирәлекләрдә актив өслекле була алуларын күрсәтә, каликсареннар ярдәмендә нанокисәкчәләрнең үзлекләрен һәм үлчәмнәрен көйләү юлларын тәкъдим итә. Тикшеренү нәтиҗәләре актив өслекле каликсареннарның судагы эремәләрен бер стеналы углерод нанокөпшәләрне — электроника өчен перспектив наноматериалларны аерып алу, чистарту һәм үлчәмнәре буенча бүлү максатында куллану мөмкинлеген бирә. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Агрегационное поведение и каталитическая активность систем на основе производных каликс[4]резорцинарена и поверхностно-активных веществ. Сообщение 1. Образование смешанных мицелл аминометилированных каликс[4]резорцинаренов и цетилтриметиламмоний бромида в среде водного ДМФА // Изв. РАН. Сер. хим. 2004. № 7 (автордаш); Агрегация и физиологическое действие на растительные клетки амфифильных каликс[4]резорцинаренов с гидроксиметилметиламидными и карбоксиметильными группами // Докл. РАН. 2007. Т. 413, № 4 (автордаш); Solubilization of single-wall carbon nanotubes in aqueous solutions of calixarenes // Phys. stat. sol. (b). 2007. V. 244, № 11 (автордаш).

**РЫЖКО́В** Вольдемар Сергеевич (15.11.1934, Казан), конструктор, Ленин бүләге лауреаты (1978). 1958 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1957 дән Казан радиоэлектроника фәнни-тикшеренү ин-тында, фәнни-техник бүлек башлыгы (1962–79), әйдәп баручы конструктор (1979–85), сектор башлыгы (1985–87), баш инженер урынбасары (1987–93). Р. җитәкчелегендә Россия з-дларында кечкенә габаритлы унификацияләнгән шифрлау-ачу аппараты эшләнә һәм серияләп җитештерүгә кертелә. Ленин бүләге «Пароль» дип аталган яңа радиолокацион тану системасын эшләгәне өчен бирелә. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

**РЫЖМА́НОВ** Михаил Артемьевич (22.5.1889, Уфа губ., Минзәлә өязе Афанасово а. — 1974, Казан), инженер-химик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1952). 1935 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген, Минзәлә а.х. уч-щесен тәмамлаганнан соң (1918), земство бүлегендә җир төзүче булып башлый. 1922 дә Казан җир төзү техникумына укырга керә, 1925 тә аны тәмамлаганнан соң, ТАССР Игенчелек халык комис-тының Җир төзүчелек һәм мелиорация идарәсендә эшли (1930 га кадәр). 1935–66 да Казан ясалма каучук з-дында: цехның полимерлаштыру төркеме мөдире, цех башлыгы урынбасары, пр-тие лаб-ясе мөдире, өлкән инженер-химик. Хезмәтләре ясалма каучук технологиясенә карый. Каучукның махсус төрләрен алу өчен җитештерүдә кулланыла торган дивинилны газ фазасыннан полимерлаштыру өчен югары нәтиҗәле яңа катализатор эшли. Дәүләт бүләге ясалма каучукның яңа төрен эшләгәне һәм сәнәгатькә керткәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Г.Я.Мәүлетова.*



М.Г. Рыжов.



М.И. Рыжов.

**РЫЖО́В** Михаил Григорьевич (25.11.1913, Сембер губ., Сембер өязе Максимовка а. — 21.4.1946, Украина ССР, Ивано-Франковск өлкәсе Городенко ш.), Сов. Союзы Герое (23.10.1943), лейтенант. Туган авылы колхозында хисапчы булып эшли. 1936–40 елларда һәм 1941 дән Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша. 1943 нең гыйнварыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 565 нче укчы полкның отделение командиры (40 нчы армиянең 161 нче укчы дивизиясе). Воронеж, 1 нче һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Белгород-Харьков операцияләрендә (1943), Днепр елгасы өчен сугышта (1943), Умань-Ботошаны һәм Дебрецен һөҗүм операцияләрендә (1944) катнаша. Днепр елгасын кичеп, Луковица авылы янында (Украина ССР, Черкассы өлкәсе Канев р-ны) батырлык күрсәтә: 1943 нең 23 сентябрь төнендә сугышчылары б-н көймәдә дошман уты астында елганы кичеп чыгып, уңъяк ярда плацдарм яулап алалар һәм полк подразделениеләре килгәнче аны тотып торалар. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медаль б-н бүләкләнә. Городенкода бер урамга Р. исеме бирелә һәм истәлек стеласы куела. Городенко р-ны Незвиско авылында Р.ка һәйкәл салына.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

**РЫЖО́В** Михаил Иванович (6.11.1922, Лаеш кантоны Уракчы а. — 12.4.1988, Украина ССР, Днепропетровск өлкәсе Кривой Рог ш.), Сов. Союзы Герое (15.5.1946), полковник. Авыл хуҗалыгын механикалаштыру техникумының 2 курсын (Казан, 1940), Очучыларның Чкалов хәрби авиация мәктәбен (1944) тәмамлый. 1940 елдан Кызыл Армия сафларында. 1944 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 103 нче авиация штурм полкында звено командиры (4 нче һава армиясенең 230 нчы авиация штурм дивизиясе). 2 нче Белоруссия фронты сугышчылары составында Белоруссияне (1944) азат итүдә, Польша (1945), Көнчыгыш Пруссия һөҗүм операцияләрендә катнаша. Сугыш вакытында Ил-2 штурмовигында, дошман гаскәрләре һәм техникасы җыелган урыннарны бомбага тоту өчен, 123 сугышчан очыш ясый. Сугыштан соңгы хезмәтен СССР Хәрби-Һава Көчләрендә дәвам итә. 1975 тән запаста. Кривой Рог шәһәрендә яши. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**РЫ́КОВ** Алексей Иванович (1.2.1881, Саратов ш. — 15.3.1938, Мәскәү) дәүләт һәм партия эшлеклесе. Чыгышы б-н крәстияннәрдән. 1900–01 елларда Казан ун-ты студенты. Казанда с.-д. оешмасы әгъзасы, Алафузовлар һәм Крестовниковлар пр-тиеләрендә эшчеләр түгәрәкләре б-н җитәкчелек итә, 1901 нең февралендә студентлар фетнәләрендә катнаша. Кулга алына, 1901 нең мартында Саратов шәһәренә сөрелә. Мәскәү, С.-Петербург һ.б. шәһәрләрдә революцион эшчәнлеген дәвам итә. Окт. рев-циясеннән соң дәүләт эшендә. 1918–21, 1923–24 тә Югары ХХС рәисе. Бер үк вакытта, 1921–24 тә, РСФСР ХКС рәисе урынбасары, 1924–29 да — рәисе, бер үк вакытта, 1924–30 да, СССР ХКС рәисе. 1920 еллар ахырында күмәкләштерү һәм индустрияләштерү вакытында гадәттән тыш чараларга каршы чыга, бу исә «ВКП(б)да уң тайпылыш» буларак бәяләнә. 1931–36 да почта һәм телеграфлар халык комиссары, СССРның элемтә халык комиссары. 1905–07, 1917–18, 1920–34 тә Коммунистлар партиясе ҮК әгъзасы (1907–12, 1934–37 дә ҮКта әгъзалыкка кандидат). 1920–24 тә ҮКның Оештыру бюросы, 1922–30 да ҮК Политбюросы әгъзасы. Бөтенсоюз ҮБК, СССР ҮБК әгъзасы. Репрессияләр чоры корбаны; үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Изб. произведения. М., 1990.

*Әд.:* Д о л г о в Е.Б. Из истории Казанской социал-демократической организации в 1900–1903 гг. // Социалистический строй: Вопросы теории и исторического опыта. К., 1990; С е н и н А.С. А.И.Рыков: Страницы жизни. М., 1993; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**РЫ́НДИН** Ядкәр (Яктор) (? — 1613 елдан соң), 1611–12 елларда Халык ополчениесе җитәкчеләренә каршы күтәрелгән Дон казаклары атаманы И.М.Заруцкийның көрәштәше. 1612 нең июль аенда атаман гаскәре Рязаньга китә. Р. 1612 нең ахырында Заруцкий ягындагы зур отряд б-н җитәкчелек итә. Переяславль-Рязанский шәһәре янына җибәрелә, Мервин Острог тирәсендәге бәрелештә җиңелә (727 кеше әсир төшә, артиллерия һәм олаулар тар-мар ителә). Тарихчы А.Л.Станиславский фаразынча, «Яңа елъязмачы»да («Новый летописец») нәкъ шушы бәрелеш турында бәян ителә; анда, Заруцкий Переяславль-Рязанскийга яу б-н юнәлә, әмма Рязань воеводасы М.М.Бутурлин тарафыннан тар-мар ителә, диелә.

*Әд.:* С т а н и с л а в с к и й А.Л. Гражданская война в России XVII в.: Казачество на переломе истории. М., 1990.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**РЫНДО́ВСКИЙ** Ипполит Александрович (13.3.1866 — 1917 елдан соң), 4 нче Дәүләт Думасы депутаты (1912–17), титуляр советник (1912). Казан губернасының Лаеш өязе Емельяново авылында 318 дис. җире була. Казан реаль уч-щесен тәмамлагач, Лаеш өязенең 1 нче участогы земство башлыгы. Думада милләтчеләр фракциясенә керә. Думаның сораулар; җир; сәүдә-сәнәгать; балыкчылык; законнарны фаразлау комиссияләре әгъзасы. 1915 тә Бөтенроссия милли союзы оештырган 32 нче күчмә отряд б-н идарә итүче Кызыл Хач җәмгыяте вәкиле итеп билгеләнә. 1917 нең мартында, Февр. рев-циясе вакыйгаларына бәйле рәвештә утары талаудан куркып, Емельяново авылына китә. 1917 нең маенда кулга алына, тиздән азат ителә. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* У с м а н о в а Д.М. Депутаты от Казанской губернии в Государственной думе России. 1906–1917. К., 2006.

**РЫНКЕ́ВИЧ** Дмитрий Ефимович (26.12.1841, Мәскәү — 4.1.1910, С.-Петербург), хокук белгече, сенатор (1906), яшерен советник (1901). Хокук белеме уч-щесен тәмамлый (С.-Петербург, 1863). 1863–66 елларда Сенатның 3 нче департаментында. 1866–68 дә Тула, 1868–76 да Мәскәү округ мәхкәмәләренең прокурор иптәше (урынбасары). 1876–94 тә Мәскәү округ мәхкәмәсе рәисе иптәше, 1894–96 да — Орлов, 1896–99 да Киев округ мәхкәмәләре рәисе. 1899–1906 да Казан мәхкәмә палатасының өлкән рәисе. 1906 дан Сенатның җинаять кассация департаментында.

*Е.Б.Долгов.*

**РЫ́ТОЕ КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама аръягында. Үтәк һәм Бизнә елгалары субүләрендә урнашкан. Спас р-ны Порфировка авылыннан 1,5 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы 0,32 *га*. Су күләме якынча 3 мең $м^3$. Озынлыгы 80 *м*, иң зур киңлеге 60 *м*. Уртача тирәнлеге 0,9 *м*, иң зур тирәнлеге 1,5 *м*. Формасы турыпочмаклыкка якын. Килеп чыгышы буенча ясалма: казылган. Суы гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта, бик йомшак, минеральләшүе түбән, болганчык, саргылт төстә. Терлекләргә су эчерү һәм сугару өчен файдаланыла.

**РЫЧКО́В** Пётр Иванович (1.10.1712, Вологда ш. — 15.10.1777, Екатеринбург ш., хәзерге Бөгелмә р-нының Спас авылында җирләнә), тарихчы, географ һәм икътисадчы. Петербург ФАнең беренче мөхбир әгъзасы (1759 елдан). 1720 дә, гаиләсе б-н Мәскәүгә күченеп килгәч, чит телләр, сәүдә эшенә һәм бухгалтериягә өйрәтү максаты б-н Р. Мәскәү тукыма ф-калары директоры И.П.Тамес карамагына тапшырыла. 1730–34 тә С.-Петербург янындагы Ямбург һәм Жабино пыяла з-длары идарәчесе, Петербург таможнясында тәрҗемәче һәм бухгалтер ярдәмчесе. 1730 еллар уртасыннан 40 елдан артык Оренбург краенда яши һәм эшли. 1734 тә Оренбург каласын нигезләргә (1735 нең августында нигез салына) урын эзләү максаты б-н Орь елгасына оештырылган экспедициягә бухгалтер итеп билгеләнә. 1737 дән Оренбург краеның беренче губернаторы В.Н.Татищев җитәкчелегендә эшли; 1740 тан Оренбург комиссиясе секретаре, 1744–60 та Оренбург губерна канцеляриясендә эшли. 1761 дән отставкада, Спас авылында үзенең утарында яши. 1765 тән Иректе икътисадчылар җәмгыяте әгъзасы. 1769 да хезмәтенә кире кайта, Оренбург тоз чыгару баш идарәсе җитәкчесе. 1777 дә Екатеринбург шәһәренә завод идарәләренең «баш командиры» итеп җибәрелә. «Оренбург губернасы топографиясе» («Топография Оренбургская...», ч. 1–2, СПб., 1762) исемле төп хезмәтендә Оренбург губернасының табигате, халкы, хуҗалыгы тасвирлана,

губернаның шәһәрләре, провинцияләре, «дистанцияләре», «ведомстволары» турында хәбәр ителә. «Оренбург губернасындагы халыкларның элеккеге һәм хәзерге яшәеше» («О разности народов внутрь Оренбургской губернии находящихся, по древнему и нынешнему их состоянию») исемле



П.И.Рычков.

бүлегендә Р. губернада яшәүче халыкларны, ш.и. татарларны тасвирлый, «татар халыклары» скифлардан килеп чыккан дип билгели, мишәрләрнең килеп чыгышын өстәмә рәвештә өйрәнергә кирәк дип исәпли (аның мәгълүматлары буенча, Уфа провинциясендәге «мишәрләр Алатырь һәм Сембер өязләреннән җыелганнар...»). Р. Каргалы һәм Бөгелмә өязләре турында яза; беренчеләрдән булып, укучыларны *Батырша* б-н таныштыра, «Оренбург губернасы топографиясе...»ндә («Топография Оренбургская...») Батырша һәм 1755 елгы баш күтәрү турында мәгълүмат, ш.у. Батырша өндәмәсенең «сыгынтысын» («экстракт») бирә. «Борынгы һәм Урта йөзләр Казан тарихыннан тәҗрибә» («Опыт Казанской истории древних и средних времён», СПб., 1767) хезмәтендә «әлегә бай тарихы булмаган Казан ханлыгы»н өйрәнүнең мөһим һәм файдалы булуын күрсәтә. Р. болгарлар турында: «...әүвәлдән килгән сәүдәгәрлекләре, һөнәрчелек төрләре белән танылган, шәһәрләрдә яшәүче көчле, бай, бик тә данлыклы халык», — дип яза. «Казан татар ханлыгы»н Олы Урданың «өзеге яисә тармагы» дип саный. Китапта Казан ханлыгы тарихыннан мәгълүмат тупланган, Казан каласына рус гаскәрләренең яулары һәм ханлыкны яулап алу тасвирлана, Казан архиепископлары, митрополитлары, монастырьлары, базарлары һәм кәсепләре, «атаклы урамнары» һәм «биналары» турында мәгълүмат бирелә. Күренекле галимнәр В.Н.Татищев һәм М.В.Ломоносов б-н аралашу һәм язышу Р.ның иҗади тормышында зур роль уйный. Р.ның фәнни белемнәре һәм Россия фәненә керткән өлеше алар тарафыннан югары бәяләнә. М.В.Ломоносов ФАндә, Р.ны сайлау өчен, мөхбир әгъза вазифасын булдыруны башлап җибәрә.

Х е з м.: История Оренбургская по учреждении Оренбургской губернии. Оренбург, 1896.

*Әд.:* П е к а р с к и й П.П. Жизнь и литературная переписка Петра Ивановича Рычкова. СПб., 1867; М и л ь к о в Ф.Н. П.И.Рычков: Жизнь и географические труды. М., 1953; М а т в и е в с к и й П.Е., Е ф р е м о в А.В. Пётр Иванович Рычков (1712–1777). М., 1991; Е ф р е м о в А.В. Пётр Иванович Рычков (историк и просветитель). К., 1997.

*И.Р.Вәлиуллин, Г.С.Сабирҗанов.*

**РЯБЕНКО́В** Николай Георгиевич (2.3.1949, Смоленск өлкәсенең Кардым р-ны Шестаково а.), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (2000). 1971 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1974 тән Казан химия-технол. ин-тында, 2001 дән Казан энергетика ун-тында. Хезмәтләре деформацияләнүче каты җисем механикасына карый. Р. пластиналар һәм сыгүләр теориясендә мәсьәләләр чишүнең асимптоталар алымы вариантын эшли. Югары уку йортларында теоретик механика укыту методикасын тәкъдим итә.

Х е з м.: Асимптотический метод в теории деформирования плотного упругого тела // Механика твёрдого тела. 2005. № 3 (автордаш); О единой асимптотической природе методов решения задач теории упругости для плит и пластин // Прикладная математика и механика. 2006. Т. 70, вып. 3 (автордаш); Основы механики. Ч. 1. Теоретическая механика. К., 2006.

**РЯБКО́В** Галим Мәҗит улы (1906 — 1.8.1977, Казан), журналист. 1930 дан «Социализм юлы» г-тасының әдәби хезмәткәре. 1950–59 да ТАССРның татар телендәге әйдәп баручы «*Совет Татарстаны*» г-тасының баш мөхәррире. Рябковның мәкаләләре иҗтимагый-сәяси тематикага, татар мәдәнияте үсеше проблемаларына багышлана. «Замана сулышы» (1960, очерклар җыентыгы), «Ишле кызы» (1961) исемле китаплар авторы.

**РЯ́БОВ** Александр Андреевич (5.11.1935, Столбище р-ны Усад а.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1985), ТР ФА мөхбир әгъзасы (1992). Казан ун-тын тәмамлый (1964). 1958–60 елларда Казанның «Теплоконтроль» з-дында. 1960–67 дә ТАССР Җәмәгать тәртибен саклау министрлыгының соц. милекне урлаулар б-н көрәш бүлеге (ОБХСС) оперуполномоченные. 1970 тән (бүленеп) Казан ун-тында, 1981–92 дә гражданлык хокукы һәм процессы каф. мөдире, 1986 дан каф. профессоры, 1987–92 дә юридик ф-т деканы. 1992–95 тә Мәскәү ун-тының Ульянов ф-лы юридик ф-ты деканы. Бер үк вакытта, 1996–2004 тә, Татар эшмәкәрлеккә булышлык итү ин-тының (ТИСБИ) гражданлык һәм эшмәкәрлек хокукы каф. профессоры. Хезмәтләре җир, экология хокукына, табигый, матди һәм хезмәт ресурсларын нәтиҗәле файдалануны хокукый яктан тәэмин итү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Предоставление и изъятие земель по советскому праву. К., 1972; Охрана права государственной собственности на землю и права землепользования в СССР. К., 1976; Ответственность за нарушение законодательства о землепользовании. М., 1981; Охрана права государственной собственности на природные ресурсы СССР. К., 1982.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

*Е.Б.Долгов.*

**РЯ́БОВ** Александр Семёнович (1893, Орёл губ., Елец өязе Паленки а. — 25.10.1964, Казан), инженер-артиллерист, химик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1948). Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Константин исем. Артиллерия уч-щесен (Петроград, 1916) тәмамлый. 1919 елдан запас батарея командиры (Казан). 1920 дән арт. дивизионы командиры, 1921 дә кече командирлар мәктәбе башлыгы (Алатырь ш.). Ф.Э.Дзержинский исем. Артиллерия академиясен (Мәскәү, 1925) тәмамлаганнан соң, шунда ук бүлек башлыгы булып эшли. 1938 дә репрессияләнә (1946 да азат ителә). 1940–41 дә 6 нчы Фәнни-тикшеренү ин-ты каршындагы СССР НКВДсының 4 нче Махсус бүлегенең аерым техник бюросында (Мәскәү) төркем җитәкчесе. 1941–64 тә (бүленеп) В.И.Ленин исем. 40 нчы Казан з-ды каршындагы 40 нчы аерым техник бюрода: төркем җитәкчесе, лаб. башлыгы. 1946 да 516 нчы з-дта бүлекчә башлыгы (Мәскәү өлкәсенең Люберцы ш.). Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләгә ату коралларының яңа үрнәкләренә дары эшләгәне өчен бирелә.

*Әд.:* К а з а к о в В.С. 210 лет на службе Родине: Казанский пороховой завод. К., 1998.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**РЯЗА́НОВО** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 26 *км* көньяк-көнбатыштарак, Әрә елгасы буенда. Даими яшәүчеләр юк. 1660 елдан Яңа Резаново исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Албаба Мальцово исеме б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 134 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 95 ир-ат; 1859 да — 91, 1897 дә — 142, 1908 дә — 182, 1920 дә — 176, 1926 да — 153, 1938 дә — 204, 1949 да — 120, 1958 дә — 115, 1970 тә — 63, 1979 да — 16, 1989 да — 4 кеше (руслар) яши.

**РЯЗА́НЬ ӨЛКӘСЕ́**, РФнең Европа өлеше үзәгендә урнашкан. 1937 елның 26 сентябрендә оештырыла. Мәйданы — 39,6 мең *км*². Үзәге — Рязань шәһәре (Мәскәүдән 200 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 1140844 (2013), татарлар саны: 1989 да — 4922, 2002 дә — 5569, 2010 да — 4941 кеше. Татарлар, тупланып, Касыйм, Ирмеш (Ермишь), Сасово р-ннарында яши. Аларның бабалары Р.ө. терр-ясенә элек-электән килеп урнаша. Ука, Цна һәм Мукшы елгалары арасындагы җирләргә төрки телле кабиләләр 11–12 йөзләрдә үтеп керә. *Касыйм ханлыгы* оештырылганчы (1450 еллар), анда *мишәрләр* яши. *Касыйм ханның* Мещерага килгән гаскәрендә Алтын Урдадан чыккан төрки телле кабилә вәкилләре була. Ханлык терр-ясенә шактый гына Казан татарлары да күченә. Аларның бер өлеше 16 йөзнең 1 нче яртысында өч тапкыр Казан тәхетендә утырган Касыйм ханы *Шаһгали* яклы була. 1552 дә Казан ханлыгын Рус дәүләтенә кушкач, Рязань якларына куылган татар феодаллары башка төркемгә керә. *Касыйм татарлары* субэтносы формалашуда ш.у. нугайлар (нугай бәкләре һәм морзаларының дружиналары составында *Касыйм* шәһәренә хезмәткә киләләр), бортас һәм башкортларның зур булмаган төркеме катнаша. 16 йөзнең 2 нче яртысыннан, Касыйм ханлыгының роле кимү һәм 1681 дә бетерелүе б-н, төрки телле халыкларның монда күченүе сирәгәя, соңрак бөтенләй туктала. Йомышлы Касыйм татарлары Рус дәүләтенең Ука елгасы ярындагы чик буйларын саклауда катнаша, хөкүмәт аларны тылмачлар, дип-

ломатия вәкилләре итеп билгели. 18 йөздән татарлар тормышында сәүдә һәм эшмәкәрлек мөһим роль уйный башлый. Рязань губернасының Касыйм өязе терр-ясендә яшәүче татарлар күн, сарык тиресе эшкәртү; Россия, Германия, Америка базарларында күн, мех әйберләр сату б-н шөгыльләнә. *Хуҗалыктан читкә китеп эшләү* киң тарала. Җир эшләреннән бушаган арада ир-атларның күпчелеге шәһәрләрдә эшкә яллана (приказчик, официант, ат караучы, урам себерүче булып эшиләр; трактир, буфет тоталар). Касыйм татарлары арасында Россиянең төрле төбәкләрендә сәүдә итүче атаклы эшмәкәрләр була. Алар Рязань губернасы мәчетләренә, мөселман уку йортларына гаять зур матди ярдәм күрсәтәләр. Сәүдәгәр Костровлар иганәсенә Касыйм шәһәрендә мәдрәсә төзелә (1838), атаклы Мәскәү иганәчесе С.Й.*Ерзин* Елатьма өязенең Әҗе (Азеево) авылында мәчет һәм Мәскәү җамигъ мәчетен (1904) төзетә. 1917 гә кадәр хәзерге *Касыйм районы* терр-ясендә берничә татар уч-щесе һәм мәдрәсә, 9 — татар, ш.и. кыз балалар мәктәбе (1900) эшли. Касыйм шәһәрендә — 2, Касыйм өязендә — дистәгә якын, Әҗе авылында 7 мәчет эшли. 1897 дә *Касыйм шәһәре мөселманнары хәйрия җәмгыяте* оеша, аның ярдәме б-н 1910 да татар һәм рус телләрендә 10 меңләп китабы булган татар китапханәсе ачыла (1919 да ябыла). «Аң» һәм «Чалгы» г-талары нәшер ителә. 1908 дә Касыймда алдынгы карашлы мөселман җәмгыяте театры оеша (1930 елларда Н.Н.Нариманов исем. Татар клубы итеп үзгәртелә, 1940 еллар башына кадәр эшли). Сугыш алды чорында Касыйм мәктәпләрендә татар балалары үз туган телләрендә укыйлар (мәктәпләргә татар басма китаплары кителә, татар классиклары китапларыннан китапханәләр оештырыла). Сугыштан соңгы елларда күп кенә татар мәктәпләре бетерелә, татар халкы б-н Казан арасында бәйләнешләр кими.

Хәзерге вакытта Р.ө. терр-ясендә Татар мәдәни үзәге һәм мөселман җирле дини оешмасы (2000 нән Касыйм шәһәрендә), мөселман дини берләшмәсе (Касыйм р-нының Шырын а.) эшли. Касыйм шәһәрендә (1999), Касыйм р-нының — Шырын (1997) һәм Ирмеш р-нының Әҗе авылларында (2004) мәчетләр бар. Касыйм мәчете каршында ислам нигезләрен өйрәнү дәресләре үткәрелә, 2002 дән «Динем» г-тасы чыга. Татарлар тупланып яшәгән р-ннарда *Корбан бәйрәме, Сабан туе* үткәрелә. Касыйм р-нының Карлар (Ахматово) һәм Сасово р-нының Бостан авылларында татар фольклор коллективлары эшли. Татар халкы тарихына бәйле архит-ра истәлекләре — Касыйм хан мәчете (15 йөз; хәзерге вакытта анда Касыйм төбәк тарихын өйрәнү музееның Касыйм татарлары этнография бүлеге урнашкан), Яңа җамигъ мәчет (1906), *Шаһгали хан тәкиясе* (1556), *Әфган-Мөхәммәд Солтан тәкиясе* (1649). Сов. Союзы Герое В.В.*Альбетков*, җәмәгать эшлеклесе С.Х.*Булатова*, партия һәм дәүләт эшлеклесе Ф.Ә.*Табиев*, җырчы З.Г.*Байрашева*, педагог С.К.*Шәкулова*, мәгърифәтче әдип З.Һ.*Һади*, шагыйрә *Гыйффәт Туташ* (З.Х.Бурнашева), дин һәм җәмәгать эшлеклесе Г.*Баязитовның* тормышлары һәм хезмәт эшчәнлекләре Рязань җире б-н бәйле.

*Әд.:* А к и м о в В.В. Касимовские татары: между прошлым и будущим. М., 2004.

**РЯ́СЕНЦЕВ** Анатолий Осипович (17.6.1889, Сембер ш. — 17.7.1942), Казан меньшевиклары җитәкчеләреннән берсе. Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлаганнан соң, Казанда антлы вәкил. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң сәяси эшчәнлек б-н шөгыльләнә башлый, меньшевиклар оешмасының Казан бюросы башлыгы. Бер үк вакытта Казан шәһәр Думасы гласные, Казанда өяз азык-төлек идарәсе һәм земство җыены рәисе. 1917 дә — 1918 нең башында Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларының Казан Советы әгъзасы, Советның эшчеләр секциясен (бүлекчәсен) җитәкли. Меньшевикларның җирле газета-журналларында басыла. 1917 нең июленнән буржуаз партияләрнең ярдәменнән баш тарта, революцион юлны һәм тирән социаль реформаларны яклап чыга. Окт. рев-циясен кабул итми, Ватанны һәм ирекне коткару ком-тының Казан бүлекчәсен (бюросын) оештыручыларның берсе һәм җитәкчесе. Большевикларның эшчәнлеген, алар тарафыннан оппозиция газеталары ябылуын, демократик һәм гражданнар иреген тыюны ачыктан-ачык гаепли. Казан Чех-словак корпусы һәм КОМУЧның халык армиясе тарафыннан яуланган вакытта партиясез эшчеләр конференциясен оештыручыларның берсе, КОМУЧны яклый, Халык армиясенә керергә өнди. Акгвардиячеләр хәрәкәтенә кушылып, Казанны ташлап китә. 1930 елларда Свердловск өлкәсенең Түбән Тагил шәһәрендә яши, «Уралмашстрой» трестының план бүлеге мөдире. 1941 нең 26 октябрендә кулга алына, 1942 нең 24 июнендә атарга хөкем ителә; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Первый год пролетарской революции в Татарии. К., 1933; Жертвы репрессий: Нижний Тагил. 1920–1980-е годы. Екатеринбург, 1999.


*С.И.Ионенко.*

# С

**САБА́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Казкаш (Мишә елгасы бассейны) елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 15,8 *км*, бассейнының мәйданы 74 *км²*. Саба р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы урман массивында Байлар Сабасы авылыннан 6 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы — Сатыш авылыннан көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 175 *м*, тамагыныкы — 83 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25%. С.ның 0,6 дан 2,9 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,42 *км/км²*. Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 134 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,09 *м³/с*. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. С. бассейнында суының гомуми күләме 0,73 млн. *м³* булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла. Елга ярында район үзәге — Байлар Сабасы урнашкан.

**САБА́ АУЧЫЛЫ́К ТЫЮЛЫГЫ́**, комплекслы. Саба һәм Кукмара р-ннары терр-ясендә урнашкан. 1977 елда оештырыла. Мәйданы 19,4 мең *га*, ш.и. урманнар 14,1 мең *га*. Поши, кабан, төлке, бурсык, сусар, гади тиен, үр куяны, ак куян, көртлек, боҗыр, соры көртлек, бытбылдык, ТРның Кызыл китабына кертелгән төрләрдән — көрән аю, ас, үләксә карчыгасы яши.

**САБА́ РАЙОНЫ́**, ТРның төньягында урнашкан. Мәйданы — 1097,7 *км²*. 1 шәһәр һәм 19 авыл җирлеген, 67 торак пунктны, ш.и. шәһәр тибындагы Шәмәрдән посёлогын берләштерә. Үзәге — шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогы. 2015 елда 31,8 кеше (2010 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 96%, руслар — 3%) яши. Шәһәр халкы — 7359, авыл халкы — 23379 кеше. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км²* га 28 кеше, 1930 нең 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр район терр-ясе Казан губернасының Мамадыш һәм Лаеш өязләренә, 1920 дән ТАССРның Арча, Мамадыш һәм Лаеш кантоннарына (1927 гә кадәр) керә. Оешкан вакытында С.р.нда 69 авыл советы, 118 торак пункт исәпләнә, 68066 (татарлар — 59366, руслар — 8700) кеше яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1935 нең 10 февралендә районның бер өлеше яңадан оештырылган *Теләче районына* бирелә (1959 нең 12 октябрендә кире кайтарыла). 1940 та районның мәйданы — 1081 *км²*, халкы — 45 мең кеше, 31 авыл советы, 83 торак пункты була. 1944 нең 19 февралендә С.р.ның бер өлеше яңадан оештырылган *Чүриле районына* бирелә (1956 нең 14 маенда кире кайтарыла). 1960 та район 1846,3 *км²* җир били, аңа 1 посёлок һәм 26 авыл советы, 126 торак пункт керә. 1963 нең 1 февралендә ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, С.р.на *Кукмара*




*районы* һәм *Тәкәнеш районының* бер өлеше кушыла. Районның мәйданы — 3197 *км²*, халык саны — 112,1 мең кеше, 2 посёлок һәм 47 авыл советы, торак пунктларның саны 253 кә җитә. 1965 нең 12 гыйнварында ТАССРда адм.-терр. бүленеш үзгәрү сәбәпле, район терр-ясе — 1914 *км²*, халык саны — 59,3 мең кеше, 1 посёлок һәм 27 авыл советы, торак пунктлар саны 135 кә кала. 1991 нең 4 октябрендә С.р.ннан Теләче р-ны бүленеп чыга.

Рельефы — елга үзәннәре б-н бүлгәләнгән калкулыклы тигезлек (биеклеге 150–180 *м*). Мишә һәм аның кушылдыклары Кече Мишә, Казкаш елгалары ага. Җирләре күбесенчә аксыл-соры, кәсле-көлсу һәм көрән-соры урман туфраклы. Терр-ясенең 24% ы — урманлык. Известь, кызыл балчык, ком, бут ташы, торф ятмалары бар. Саклаулы табигать истәлекләре: *Мишә аучылык тыюлыгы, Саба аучылык тыюлыгы, Мишә* елгасы. Район терр-ясендә башлыча Алтын Урда чорына караган 30 дан артык археол. истәлек табыла. С.р.нда а.х. тармаклары: мөгезле эре терлек, сарык үрчетү алга киткән. А.х. җирләре — 71,5 мең *га*, ш.и. сөрүлекләр — 61,5 мең *га* (2013). Көзге арыш, сабан бодае, солы, арпа, борчак, җитен үстерелә; бәрәңге игелә. 2015 тә районда 25 крәстиян-фермер хуҗалыгы эшли. Сәнәгать пр-тиеләре район үзәгендә, *Шәмәрдән* авылында (ит комб-ты, мех ф-касы, икмәк кабул итү пр-тиесе) урнашкан. Районда Саба урман хуҗалыгы бар. С.р. терр-ясеннән Казан–Екатеринбург тимер юлы, Казан–Шәмәрдән автомобиль юлы уза. Районда 9 филиаллы 23 гомуми белем бирү мәктәбе (ш.и. 2 тулы булмаган урта, 20 урта мәктәп, 1 махсус коррекция интернат-мәктәбе), аграр көллият, 47 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, балалар сәнгать мәктәбе, балалар иҗат үзәге; район мәдәният йорты, 42 авыл клубы; 29 китапханә; төбәк тарихын өйрәнү музее, Саба урманчылыгы тарихы музее, район хастаханәсе, Шәмәрдән авылында участок хастаханәсе, Лесхоз посёлогында һәм иске Икшермә авылында дәвалау амбулаториясе, 41 фельдшер-акушерлык пункты, «Хәрәкәт» мед. үзәге, районара күз авырулары хирургиясе үзәге; «Сабантуй», «Олимп» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе, «Яшьлек» яшьләр спорт үзәге, 2 мәдәни-спорт комплексы, районара мәдәни-спорт үзәге, «Нарат» ясалма боз спорт комплексы, «Саба» йөзү бассейны, 33 спорт залы, 16 хоккей мәйданчыгы бар. «Саба дулкыннары» телерадиокомпаниясе эшли. Татар телендә «Саба таңнары» район г-тасы нәшер ителә.

**САБА́ ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕ́Е**, Байлар Сабасы авылында, ТРның Милли музее ф-лы. 1993 елда ачыла. Экспозиция мәйданы — 78,15 *м²*, музей коллекцияләре 3 меңгә якын саклау берәмлеген тәшкил итә. Экспозиция





Байлар Сабасы авылындагы төбәк тарихы музее. 1. Экспозициянең гомуми күренеше; 2. Экспозиция фрагменты.

авылның табигатенә һәм тарихына багышлана. Күргәзмәгә палеонтология (мамонтның казык тешләре) һәм археология (р-н терр-ясендәге борынгы авыл казылмаларыннан) коллекцияләре куела. Этнография бүлегендә көнкүреш әйберләре, өс киемнәре, татар халкының 19 йөз — 20 йөзнең 2 нче яртысына караган декоратив гамәли сәнгате эшләнмәләре урнаштырылган. Экспозициянең Саба р-нында туып үскән танылган шәхесләргә багышланган бүлекләрендә Ә.Г.*Кәримуллинның* үзе бүләк иткән китаплары, сынчы К.Ж.*Җәмитов*, Сов. Союзы Герое В.Х.*Хаҗиев*, Дан орденының тулы кавалеры Г.М.*Мотыйгуллинның* документлары, автографлы китаплары, мемориаль әйберләре куелган. Шулай ук К.Ж.Җәмитовның 10 әсәре (аның музейга бүләге), ш.и. «Тукай һәм Әмирхан» композициясе урын алган. Музей ел саен Байлар Сабасы авылында туган композитор Х.Б.*Вәлиуллинның* туган көнен (28 фев.) уздыра.

**САБА́ УРМАНЧЫЛЫГЫ́**. Арча, Балтач, Биектау, Кукмара, Мамадыш, Питрәч, Саба һәм Теләче р-ннары терр-ясендә урманнарны файдалану, аларны саклау һәм яңадан утырту буенча идарә эшләрен алып бара. 1930 елда Саба урман сәнәгате хуҗалыгы буларак оештырыла. 1931–63 һәм 1992–2007 дә — Саба урман хуҗалыгы, 2010 нан ТРның «Саба урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе. С.у.ның гомуми мәйданы 60381 *га*. 6 урманчылык — Кукмара (4603 *га*), Курса (6360 *га*), Ленин (12346 *га*), Мишәбаш (11997 *га*), Сабабаш (12443 *га*), Шәмәрдән (12633 *га*) участокларыннан тора. Урман б-н капланган мәйдан 56993 *га*, ш.и. ылыслы токымнар 22386 *га*, каты яфраклылар — 6306 *га*, йомшак яфраклылар — 28239 *га*, куаклар 62 *га* тәшкил итә. Урман барлыкка китерүче төп токымнар: чыршы (22,5%), каен (19,5%), юкә (20,6%), нарат (15,9%), биек кәүсәле имән (10,1%), усак (6,7%). Шулай ук соры зирек, очлы яфраклы өрәңге, Себер карагае, Себер ак чыршысы, тәбәнәк кәүсәле имән, тополь, кара зирек, агачсыман таллар таралган. Өстенлек итүче урман типлары: юкә, ара-тирә чикләвек куагы һәм имән катнаш чыршылык һәм акчыршылыклар, катнаш наратлыклар, өрәңге, юкә катнаш имәнлек, төрле үләнле юкәлек, сырмавыклы усаклык һәм каенлыклар. 2002 дә 11,35 *га* мәйданда дендрология бакчасына нигез салына, анда Европа, Азия, Америка илләреннән китерелгән агач һәм куак токымнарының 490 нан артык төре үстерелә. 2011 дә утырту материалы (ябык тамыр системалы 12 млн.га кадәр үсенте) үстерү өчен селекция-орлыкчылык үзәге булдырыла. С.у. терр-ясендә табигать истәлекләре: Мишәбаш акчыршылыклары (к. *Порфирьев акчыршылыгы*) — ареалның көньяк чигендәге ак чыршы урманы участогы, *Кукмара тавы* — текә тау битләрендәге кеше тарафыннан утыртылган наратлыклар урын алган. С.у. базасында агачны әзерләү, читкә чыгару, эшкәртү буенча бүлекчәләр эшли. Агач әзерләү Скандинавия технологиясе буенча алып барыла, өч сменалы эш оештырылган, көндәлек җитештерүчәнлек 300–320 *м*³ тәшкил итә. Халык кулланeasy товарлары, сувенирлар ясыйлар. С.у.ның оешуына һәм үсешенә ТР һәм РФнең атказ. урманчысы Н.М.*Миңнеханов* (1962–1990 да урман хуҗалыгы директоры) зур өлеш кертә. Күп кенә хезмәткәрләрнең эшчәнлеге, СССРның (Х.Ф.Галиев), ТРның (Н.М.Миңнеханов, Р.Н.Миңнеханов, В.Н.Гыйззәтуллин, М.С.Галиев, Н.В.Газизов, М.Н.Сибгатуллин) Дәүләт бүләкләре, орденнар (Н.М.Миңнеханов, Н.Ш.Шакиров, Н.Н.Сафин, С.Г.Галиев) б-н билгеләнә; М.С.Галиев, Н.В.Газизов, Р.И.Галимов, М.Н.Сибгатуллин, Д.М.Рәхмәтуллин, Р.Н.Миңнеханов, З.Г.Мултанова, Л.К.Сәгыйтова, Г.А.Абдуллин, В.З.Нурмөхәммәтов, Р.М.Талипов ТРның атказ. урманчысы исеменә лаек була. С.у. урман хуҗалыгы һәм агач әзерләү эшләрен алып баруның алдынгы технологияләрен эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә база, ш.у. бөтенроссия семинар һәм киңәшмәләр үткәрү урыны булып тора.

*А.Х.Газизуллин, В.Н.Гыйззәтуллин.*

**САБАБА́Ш** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 11 *км* көнчыгыштарак, Казкаш елгасы буенда. 2010 елда 480 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мунчала ясау пр-тиесе. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. Рус чыганакларында беренче исеме — Пустошь Гожинская, 1920 елларга кадәр — Гожинская (Гажинская) Пустошь. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 962 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Сатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 48 ир-ат; 1859 да — 384, 1897 дә — 577, 1908 дә — 692, 1920 дә — 729, 1926 да — 774, 1938 дә — 471, 1949 да — 550, 1970 тә — 608, 1979 да — 518, 1989 да — 437, 2002 дә — 482 кеше.

**САБАВИ́**, к. *Җамалетдин бине Шәмсетдин.*

**САБА́Й** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 10 *км* көнбатыштарак, Кече Мишә елгасыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 65 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. Беренче исеме — Яңа Шинар. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 888,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Сатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 73 ир-ат; 1859 да — 417, 1897 дә — 550, 1908 дә — 648, 1920 дә — 649, 1938 дә — 488, 1949 да — 433, 1970 тә — 412, 1979 да — 364, 1989 да — 176, 2002 дә — 115 кеше.

**САБАКА́Й** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 9 *км* көньяк-көнбатыштарак, Көрнәле елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 55 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1690 нарда чуашлар нигез сала. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.да чиркәү (1910 да яна), земство мәктәбе (1882 дә ачыла), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1042 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Алексеев волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1921–22 еллардан Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 61 ир-ат; 1859 да — 872, 1897 дә — 661, 1908 дә — 938, 1920 дә — 896, 1926 да — 725, 1938 дә — 528, 1949 да — 306, 1958 дә — 280, 1970 тә — 173, 1989 да — 93, 2002 дә — 84 кеше.

**САБАКА́Й КҮЛЕ́**, Идел алдында. Идел елгасының уңъяк ярында, Яшел Үзән р-ны Улитино авылыннан 0,9 *км* көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы 0,09 *га*. Су күләме 3,5 мең *м*³. Озынлыгы 30 *м*, киңлеге 30 *м*. Уртача тирәнлеге 3,9 *м*, иң зур тирәнлеге 7,2 *м*. Күл карст процесслары нәтиҗәсендә хасил булган. Формасы түгәрәк. Ярлары текә, күтәренке. Туенуы җир асты сулары исәбенә, тотрыклы. Суы гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта, җиңелчә минеральләшкән (62,5 *мг/л*), йомшак (1,9 *мг-экв/л*). Үтә күренмәлелеге 80 *см*. ТРның табигать истәлеге (1978). Ял итү урыны.



Сабакай күле.

**САБАКҮ́Л**, Көнбатыш Кама алдында. Идел елгасыгың югары террасасында, Лаеш р-ны Сапуголи (Сабакүл) авылы терр-ясендә урнашкан. Су өслегенең мәйданы 8,1 *га*. Су күләме 80 мең *м*³. Озынлыгы 765 *м*, иң зур киң-



Сабакүл.


леге 157 *м.* Уртача тирәнлеге якынча 1 *м*, иң зур тирәнлеге 3,7 *м.* Формасы — озынча түгәрәк, урта өлешендә кысылган. Күл казанлыгы термокарст процессы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Төньяк яры тәбәнәк һәм сөзәк, көньягы текә һәм күтәренке. Туенуы тотрыклы, күбесенчә җир асты сулары исәбенә. Суы гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта, җиңелчә минеральләшкән (114,4 *мг/л*), бик йомшак (2,5 *мг-экв/л*), саргылт төстә. Суының үтә күренмәлелеге 90 *см.* Ял итү максатларында һәм суы сугару өчен файдаланыла. Күл ләмләнә һәм үсемлекләр б-н каплана бара. ТРның табигать истәлеге (1978).

*Әд.:* Т а й с и н А.С. Озёра Приказанского района, их современные природные и антропогенные изменения. К., 2006.

**САБАКУ́Л**, к. *Сапуголи*, Лаеш р-ны.

**САБАКУ́Л**, урта гасырлар Идел буе Болгар дәүләте шәһәре, Чулманның түбән агымында, сулъяк ярда яки Чулман аръягында, көнбатыш юнәлештә урнашкан була. Рус елъязмаларында рус кенәзләренең 1183 елда Биләргә оештырган явы б-н бәйләп телгә алына.

**САБА́Н**, җир эшкәртү коралы. 1) Авыр С. зур һәм ныклы корпустан, киң төрәннән, кискеч-пычактан һәм тәгәрмәчле арбаның алгы өлешеннән (еш кына арбадан) тора. С.ны эшкә җигелә торган берничә ат яисә үгез тарта. Чирәм, яткын җирләрне һәм тыгыз кәсле туфракны сөрү өчен кулланыла. Урта Идел буенда монголларга кадәрге чордан билгеле — Идел буе Болгар дәүләтенең археол. истәлекләрен казулар барышында сабан төрәннәре һәм кискечләре табыла (10–13 йөзләр). 19 йөз ахырында – 20 йөз башында традицион С.ны һөнәрчеләр эшләгән һәм сәнәгый җитештерелгән сабаннар алыштыра. 2) Җиңел С. Элек С.ны агачтан эшләгәннәр, хайваннарны җигү өчен сыңар тәртәсе һәм идарә



Идел буенда кулланылган сабан. 18–19 йөзләр.

итү өчен тоткычы булган. С.ның эшче органы — төрән — горизонталь (С. үзе) яисә авыш беркетелгән (сука). Б.э.к. 1 нче меңьеллыкта тимер төрәнле С.нар барлыкка килә; римлылар тарафыннан С.ның сөрү тирәнлеген көйләүче алгы көпчәкләр уйлап табылган; соңрак төрән алдына «пычак» (җир катламын кисү өчен) һәм төрәнгә почмаклап беркетелгән такталар (калаклар) (туфракны ваклау һәм як-якка җибәрү өчен) куя башлыйлар. Россиядә С. 8–9 йөзләрдә урманлы-далалы полосада барлыкка килә.

С. (Идел буе яисә татар С.ы) Идел буе Болгар дәүләте чорыннан билгеле. Сабанны камилләштерә башлау 17 йөзләргә карый. Беренче атлы металл С.нар 18 йөз ахырында барлыкка килә. С.ны заводта җитештерү Россиядә 1802 елда башлана. Алгы арбасыз яисә көпчәкле алгы арбалы (рус арбасы) С. җитештерелгән. Механик тартулы С.нар чыгару — 1917 ел ахырында, тагылмалы трактор С.нарын серияләп җитештерү 1925 тә Одесса з-дында башлана. Алга таба С.ны өзлексез камилләштерү бара. Аларны гомуми кулланыштагы С.нарга — җирне 20–35 *см* тирәнлектә әйләндереп салып яисә әйләндереп салмыйча сукалый торган һәм туфракны махсус эшкәртә торган С.нарга аералар. С.ны тарту төре буенча – атлы, трактор, аркан б-н тарта торган һәм үзйөрешлеләргә; агрегатлаштыру ысулы буенча тагылмалы, асылмалы, ярымасылмалы; эшли торган орган төрләре буенча — төрәнле-сукалы, дисклы, роторлы һәм 1 дән 10 га кадәр корпуслы катнаш төрләргә бүләләр.

ТРда, башлыча, гомуми кулланыштагы төрәнле-сукалы трактор С.нары, ш.у. КАМАЗның коюу заводы тарафыннан үзәкләштерелмәгән заказ буенча җитештерелә торган гади С.нар кулланыла. 2000 нән, аеруча шикәр чөгендере үстерүче районнарда, әйләндермә төрәнле, 10 корпуслы К-700 тибындагы тракторлар б-н агрегатлаштырылучы С.нар киң таралыш ала. Сай сөрү өчен алтөрәнле С.нар яисә яру сабаннары файдаланыла. Сөрүнең төренә бәйле рәвештә корпусларның эшли торган өслеге культиватор тибында, ярымвинтлы яисә винтлы типта булырга мөмкин, ш.у. югары тизлектә эшләү өчен (сәгатенә 12 *км* га кадәр) аерым модификацияләре бар. Корпусның состав өлеше — җир катламнарын кисүче төрән һәм туфракны ваклаучы калак. Алтөрән туфрак катламының өске өлешен кисеп буразнаның төбенә ташлый. Пычак корпус алдындагы катламның ян-ягын кисә. Туфрак тирәнәйткеч сөрелә торган туфракның аскы катламын өскә чыгармыйча гына йомшарта.

Татарстанның а.х. оешмаларында трактор сабаннары саны (мең данә): 1933 тә — 2,3; 1940 та — 7,2; 1960 та — 8,8; 1980 дә — 16,1; 1990 да — 12,9; 2000 дә — 9,4, 2013 тә — 4,5. Хәзерге көнгә кадәр сакланган атлы С.нар бары тик шәхси хуҗалыкларда гына кулланыла. Ш.у.к. *Авыл хуҗалыгы.*

*Әд.:* Плуги и другие улучшенные сельскохозяйственные орудия в крестьянском хозяйстве Казанской губернии. К., 1905; Г о р я ч к и н В.П. Какие бывают плуги. М., 1908; ш у л у к. Плуги и лущильники. М.–Л., 1936; С а б л и к о в М.В. Сельскохозяйственные машины. Ч. 1. Устройство и работа. М., 1968; Х о в а н с к и й В.М. Экскурсия за плугом. М., 1974; С к о р н я к о в С.М. Плуг: крушение традиций. М., 1989; Х а л и к о в Н.А. Традиционное хозяйство // Татары. М., 2001; Этнография татарского народа. К., 2004.

**«САБА́Н»**, атналык рәсемле иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Казакъстан өлкә ком-ты органы. 1924 елның гыйнварыннан Оренбургта, 1925 тә Кызыл-Урда (Казакъстан) шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 74 саны басыла. 1924 нең 30 июленә кадәр «Юл» исеме б-н чыга. 1924 нең 6 августыннан «С.» дип атала башлый. Мөхәррире — З.Шәркый. Казакъстан авылларында яшәүче татар-башкортларга адреслана. Авторлары арасында — З.Гыймадетдинов, С.Гомәрова, Х.Дәүләтшин, З.Ильский, А.Кушай, Х.Морат, Ф.Мөсәгыйтов, Г.Мөхәммәтшин, М.Рәфыйков, Х.Рәхмәти, М.Сәйфуллин һ.б. Төп рубрикалары: «Советлар илендә», «Партия тормышыннан», «Авылларда», «Эшчеләр тормышыннан», «Театр һәм әдәбият», «Чит илдә». Авыл хуҗалыгы алдынгыларының фотосурәтләре һәм кыскача биографияләре басыла. Газета пионер һәм комсомол оешмалары эше б-н таныштыра; ачлар һәм ятим балалар хакына акча җыюда катнашырга чакыра.

**САБА́Н ТУЕ́**, татарларның борынгыдан килгән бәйрәме. С.т. турында иң элгәреге хәбәр 13 йөз ахырына карый (1292 елга нисбәтле эпиграфик истәлектә, Әлки р-ны Иске Салман авылында табыла). Баштарак С.т. бер тирәлеккә (*җыенга*) караган авыл кешеләре тарафыннан билгеле бер тәртиптә язгы чәчү башланганчы үткәрелә. С.т. үткәрүнең катгый билгеләнгән көне булмый: бәйрәмне кар бетү һәм язгы ташу китүгә карап (гадәттә, апрель ахырында) уздыралар. Татарстанда С.т. зур вакыйга булып исәпләнә, шуңа күрә аңа алдан әзерләнәләр: спорт ярышлары, ат чабышы һ.б. өчен мәйдан билгелиләр; егетләр уенда һәм алышта катнашучылар өчен бүләкләр җыялар (к. *Сөрән*). Бәйрәм чараларын уздыру б-н авылның өлкәннәре (аксакаллар) җитәкчелек итә, алар ярышларны уздыру тәртибен раслый, судьяларны, җиңүчеләрне билгели һ.б. С.т. көнне бәйрәм җитәкчеләре мәйдан уртасына җыелган бүләкләрне алып чыгалар. Аларның төркемен сөлгеләр, тукыма кисәкләре, махсус чигелгән кулъяулыклар бәйләнгән озын колга тоткан ир-ат җитәкли. С.т.н оештыручылар колганы җиргә казып утырталар, аның тирәли мәртәбәле кунаклар, судьялар һәм жюри әгъзалары урнаша. Бәйрәмчә киенгән-ясанган авыл кешеләре мәйданга гаиләләре б-н, төркем-төркем булып киләләр; атларның ялларын төрле төстәге тасмалар үреп, дугаларын төсле тукыма яки чигүле сөлгеләр б-н урап бизиләр. Бәйрәм, гадәттә, ат чабышыннан башлана; узышта катнашучылар, бергә җыелып, старт урынына китәләр; финиш мәйдан б-н янәшә билгеләнә. Ат чабышы барганда, мәйданда йөгерү ярышлары уздырыла. Ярышучыларны яшь буенча бүләләр: малайлар, егетләр, өлкәннәр. Йөгерә торган ара 3 *км* дан артмый. С.т.нда билбаулы яисә сөлгеле *көрәш* зур җанлану тудыра. Һәр көрәшче үзенең сөлгесе б-н көндәшен, биленнән кысып алып, аркасына салырга тырыша. Барлык алышлардан соң да җиңелмәгән көрәшче С.т. батыры булып кала. Батырлар халык арасында зур ихтирам казана. Ат чабышында җиңүчеләр б-н бергә, аларга иң яхшы бүләкләр тапшырыла (гадәттә, тәкә, ш.у. кайбер очракларда — җиңел автомобиль, кыйммәтле көнкүреш техникасы). 19 йөзнең 2 нче яртысыннан С.т.ларында күңел ачуга корылган уеннар һәм ярышлар уздырыла башлый: капчык киеп йөгерү, берәр аякны бәйләп, парлап йөгерү, авызга йомырка куелган кашык кабып йөгерү, күзләрне бәйләп балчык чүлмәк вату, бүрәнәгә атланып, печән яки салам тутырылган



**Сабан туе.** Казан. 1. Үзәк мәйдан; 2–6. Төрле ярышлар; 7. Ат чабышы; 8. Милли көрәш ярышлары; 9. Милли көрәш батыры.

капчыклар б-н сугышу, аркан тартышу һ.б. 19 йөз ахырында шомартылган биек багана башына менү ярышлары киң тарала, аның иң очына куелган читлектә тере әтәч яисә башка бүләкләр урнаштырыла. Бу көнне һәр йортта бәйрәм ризыклары әзерләнә. Яшьләрнең мәйданда һ.б. ачык урыннарда (болында яисә аланда) оештырылган кичке уеннары С.т.ның аерылгысыз өлеше булып тора. Бәйрәмчә киенгән егетләр һәм кызлар төнгә кадәр җырлыйлар, бииләр, түгәрәк уен уйныйлар.

Совет чорында С.т.н уздыруның бердәм вакыты билгеләнә — ул июнь аенда, язгы кыр эшләре тәгәлләнгәч үткәрелә башлый. 1992 елда ТРда ул закон б-н расланган респ-ка бәйрәмнәре исемлегенә кертелә. Район һәм шәһәр С.т.н уздыру вакыты ел саен ТР МК яисә ТР Президенты Указы б-н билгеләнә. Башта С.т. аерым авылларда һәм район үзәкләрендә (шимбә һәм якшәмбе көнгә туры китереп), алдагы атнада зур шәһәрләрдә, аннары Казанда уздырыла. 1990 еллар ахырыннан башлап, С.т. Россия һәм дөньяның татарлар тупланып яшәгән күп кенә шәһәрләрендә (Мәскәү, Самара, Саратов, С.-Петербург, Новосибирск, Ташкент, Берлин, Прага, Хельсинки, Истанбул һ.б.) бәйрәм ителә. 2001 дән Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма ком-ты һәм татарларның төбәк иҗтимагый оешмалары б-н берлектә җирле хакимият органнары булышлыгы б-н татарлар яшәгән зур төбәкләрдә ел саен федераль С.т. уздырыла башлый (Саратов, 2001; Тольятти, 2002; Димитровград, 2003; Мари Респ-касы, 2004; Түбән Новгород, 2005; Саранск, 2006; Чиләбе, 2007; Әстерхан, 2008; Ульянов, 2009; Ижевск, 2010; Владивосток, 2012; Төмән, 2013; Томск, 2014; Красноярск, 2015; Түбән Новгород, 2016).

РФ төбәкләрендә С.т. бәйрәмен әзерләүдә булышлык күрсәтү максатыннан, 2003 нең 18 августында ТР МК «Россия Федерациясе төбәкләрендә халыкның милли бәйрәме «Сабан туе» турында» карар кабул итә, анда С.т.н алдагы елларда уздыруның төбәкләр җитәкчелеге б-н килешенгән планы раслана. Ш.у.к. *Халык уеннары*.

*Әд.:* Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Уразманова Р.К. Современные обряды татарского народа: Ист.-этногр. исслед. К., 1984; шул ук. Обряды и праздники татар Поволжья и Урала (годовой цикл XIX — нач. XX вв.). К., 2001; Шарафутдинов Д.Р. Исторические корни и развитие традиционной культуры татарского народа. XIX — начало XXI вв. К., 2004; Этнография татарского народа. К., 2004; Шарафутдинов Д.Р., Садыкова Р.Б. Семейные и календарные обычаи и обряды татар. К., 2012.

*Р.Р.Батыршин.*

**«САБА́Н ҺӘМ ЧҮКЕ́Ч»**, газета; к. «*Социализм юлы*».

**«САБАНТУ́Й»**, балалар һәм яшүсмерләр газетасы. 1924 елның 10 октябреннән Казанда татар телендә нәшер ителә, атнага 2 тапкыр чыга, 2002 дән — атналык газета. Оештыручысы — «Татмедиа» АҖ. Исеме үзгәрә: 1941 нең 8 июленә кадәр һәм 1961–90 да — «Яшь ленинчы», 1991 дән хәзерге исемендә. РЛКСМның Татар-башкорт үзәк бюросы, РЛКСМ Татарстан өлкә ком-ты һәм яшь пионерларның өлкә бюросы органы, аннары ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты һәм пионер оешмаларының Респ-ка советы органы. 1936–41 дә редакция «Красная Татария — Кызыл Татарстан» г-таларының берләшкән редакцияләре составында эшли. 1990 елларда оештыручылары — ТР Мәгариф министрлыгы, ТР яшьләр оешмалары советы, Татарстан балалар фонды. Төрле еллардагы мөхәррирләре – Ш.Шаммазов, К.Зәлиев, Л.Г.*Гыйльми*, Г.М.*Мөхәммәтшин*, Г.Кети, Г.З.*Галиев*, Г.Хәбибуллин, В.Ф.Ихсанова, Р.Р.*Туфитуллова*, Р.М.*Миңнуллин*, Л.Н.*Гыймадиева*, А.М.Гыймадиев; 2017 дән – И.Ф.Фазлуллин. Газетаның беренче авторлары арасында — танылган татар язучылары А.Алиш, М.Җәлил, Ә.Еники, Һ.Такташ, Х.Туфан, А.Шамов, ш.у. яшь язучылар М.Вәдүт, М.Гаяз, З.Нури, Ш.Мөдәррис, М.Садри, Г.Хуҗи, М.Хөсәен. 1930 да газетаның җаваплы сәркәтибе — Ф.*Кәрим*. 1930 елларда редакция кар-

шында А.Алиш оештырган әдәби түгәрәк эшли. Түгәрәк әгъзалары Г.Хәсәнов б-н Г.Галиуллин ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты оештырган балалар әдәби әсәрләре конкурсы җиңүчеләре була. Газета чыкмый торган арада (1941–60) «Кызыл Татарстан» г-тасында «Пионер бите» дигән сәхифә алып барыла, аның материаллары «Яшь ленинчы»ның элеккеге журналистлары М.Дибаева, М.Нуретдинова тарафыннан әзерләнә. 1960 елларда газетаның традицияләрен журналистлар З.Гыйләҗев, Х.Зарипов, С.Ибраһимова, Ә.Сәләхетдинов, И.Сәмигуллина, М.Шабаев, Р.Шакирова, Р.Яхина, Ф.Хәмидуллин һ.б. дәвам итә. Күренекле рәссамнар Х.Якупов, Л.Фәттахов, Т.Хуҗиәхмәтов, Л.Насыйров һ.б. эшли.

Редакция табигатькә сакчыл караш тәрбияләүгә юнәлдерелгән «Туган ягым — яшел бишек» операцияләрен уздыра. 1960–70 елларда газета Окт. рев-циясе һәм Бөек Ватан сугышы геройларын эзләү буенча «Лачын» программасын оештыра, Совет Армиясе һәм флоты тарихы, чит илләрдәге пионер оешмалары тормышы б-н таныштыра. 1975 тә газетада Бөек Ватан сугышы башында Латвиянең «Кроте» пионер лагереннан Арча р-ны Мәңгәр авылына эвакуацияләнгән балалар турында язмалар басыла; 1980 дә редакция алар б-н Казанда очрашу оештыра. Күп кенә мәкаләләр хезмәт тәрбиясе, өлкәннәргә ярдәм итү, киләчәккә һөнәр сайлау темаларына багышлана. Әдәби иҗат дәресләре б-н танылган язучы һәм шагыйрьләр Т.Миңнуллин, И.Юзеев, Р.Харис, Г.Гыйльманов һ.б. чыгыш ясый. 1990 да балалар иҗатына зур игътибар бирелә башлый: газетада аларның шигырьләре, хикәя, әкиятләре басыла. Газета үзенең битләрендә атаклы балалар язучылары И.Юзеев, Ш.Галиев, Р.Миңнуллин, Л.Ихсанова һ.б.ның әсәрләренә урын бирә. Татар мәдәниятенең мәшһүр эшлеклеләре б-н таныштыра торган сәхифәләр әзерләнә. Даими рубрикалар арасында — «Татарстан тарихы», «Өмет», «Татар педагоглары», «Туган тел», «Яшүсмер». Редакция балалар язучыларының китапларын, балалар өчен җырлар, уеннар, әдәби әсәрләр җыентыкларын аерым басма итеп чыгара. РСФСР ЮС һәм ВЛКСМ ҮКның Мактау грамотасы (1974), балалар әдәбияты өлкәсендәге уңышлары өчен Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исем. бүләге лауреаты (1999). 2014 тә «Сабантуй» г-тасы журнал булып чыга башлый.

*Әд.:* Малкин И.И., Носов С.С., Яруллин Ш.К. Марш пионерии Татарстана. К., 1973.

*Р.А.Айнетдинов.*



1, 2, 3

1–2. «Яшь ленинчы»; 3. «Сабантуй» газеталары.

**САБАНЧЫ́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 17 *км* көнбатыштарак, Кичү елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 55 кеше (татарлар) яши. 1924 тә Яңа Кәшер авылыннан күченүчеләр нигез сала, 1929 га кадәр Социализм исеме б-н билгеле. Оештырылган көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Әлмәт волостенда. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 109, 1938 дә — 160, 1949 да — 102, 1958 дә — 89, 1970 тә — 55, 1979 да — 32, 1989 да — 8, 2002 дә — 4 кеше.

**САБАНЧЫ́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 21 *км* көнбатыштарак, Бөре елгасы буенда. 2010 елда 141 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — нәселле терлек үрчетү. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. С. исеме б-н 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Аты буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мех эшкәртү, баш киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1108,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Ядегәр волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 120 ир-ат; 1859 да — 476, 1897 дә — 563, 1908 дә — 679, 1920 дә — 690, 1926 да — 580, 1938 дә — 591, 1949 да — 390, 1958 дә — 334, 1970 тә — 287, 1979 да — 230, 1989 да — 148, 2002 дә — 151 кеше.

**«САБАНЧЫ́»**, атналык иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Пенза губерна ком-ты һәм губерна башкарма ком-ты органы. 1922 елның 18 маеннан 1928 нең 4 октябренә кадәр Пенза шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. 1925–28 дә «Крәстиян журналы» дигән кушымта чыгара. Мөхәррире — И.Агишев. Редакция авыл халкын илдә һәм чит илләрдәге вакыйгалар б-н таныштыруны; шәһәр һәм авыл, эшче һәм крәстияннәр арасындагы элемтәне ныгытуны; а.х.на яңа чаралар кертүне пропагандалауны төп максат итеп куя. Авторлары арасында — Г.Ахунов, Г.Биги, Г.Виргасов, Г.Гали, Х.Дашкин, Г.Еникиев, Г.Кәрим, М.Маньоров, М.Осипов, Х.Ризван, Н.Сокольский, Г.Субаев. Кооперация, терлекчелек, бакчачылык, умартачылык, авыл ярлыларының җәмәгать эшчәнлеген оештыру, белем дәрәҗәләрен күтәру, ачлык б-н көрәш, соц. җәмгыять төзүдә хатын-кызның роле турындагы язмалар, танылган сәяси эшлеклеләрнең биографияләре, җитештерү һәм а.х. алдынгыларының фотосурәтләре басыла. 1 нче Бөтенроссия эшче һәм крәстияннәр съездының эше яктыртыла.


**«САБА́Х»**, Казандагы китап нәшер итү һәм китап сату фирмасы. 1906 елда Казан ун-ты басмаханәсенең элеккеге хезмәткәрләре абыйлы-энеле Г.М. һәм М.М.Әхмәдуллиннар тарафыннан 1902 дән эшләп килүче «Көтебханәи ибтидаи» китап кибете җирлегендә оештырыла. 1908 дән устав капиталы 16 мең сум булган «Габделвәли Әхмәдуллинның «Сабах» ширкәте» итеп үзгәртелә, аңа Ш.Ш.Әхмәров, Г.Г.Гыйльфанов, С.С.Гобәйдуллин, А.Г.Дәүләтшин-Хөсәенов, Х.А.Зәбиров, М.З.Фәйзуллин, М.Ш.Хәлфин керә. Ширкәтнең Казанда һәм Уфада китап кибетләре була. 1909 да һәм 1911 дә Казан губернаторы Г.М.Әхмәдуллинның нәшрият ачу турындагы үтенечен кире кага. 1912 дә Казан ун-ты басмаханәсе башлыгы А.Т.Соловьёв булышлыгы б-н ширкәт тарафыннан «Өмид» басмаханәсе ачыла (шул ук елда басылган татар китаплары саны буенча бертуган Кәримовлар басмаханәсеннән генә калыша). «С.» басмаларының күп өлешен Г.Тукай, Г.Камал, М.Гафури, К.Насыйри, З.Бәшири, С.Сүнчәләй һ.б. татар язучылары әсәрләре, популяр һәм белешмә басмалар, гамәли кулланмалар, дәреслекләр һәм К.Бәшири, Н.Думави, Г.Ибраһимов, Ш.Мәрҗани, Ш.Рәхмәтуллин, Х.Фәйзи һ.б. авторларның уку китаплары; татар һәм кыргыз фольклор әсәрләре, рус әдәбияты һәм фольклоры әсәрләре тәрҗемәләре; юл күрсәткечләр, календарьлар, геогр. карталар һ.б. алып тора. «Яңа мәктәп китапханәсе» китаплары сериясе барлыкка килә. Аларга белем бирүнең барлык юнәлешләренә караган әсәрләр һәм киң катлау укучыга адресланган матур әдәбиятның тәрҗемә әсәрләре керә («С.»ның басмалары һәм китап сәүдәсе ассортименты каталогларда чагыла). 1911–17 елларда «Өмид» басмаханәсендә гомуми тиражы 1347575 данә б-н исәпләнгән 401 китап басыла (аларның якынча яртысы «С.» ширкәте басмалары), 1918–21 дә тиражы 140000 данә булган 60 исемдәге китап (алар арасында — Ә.Гыйсмәти һәм М.Туктаровның татар теле, Г.Ибраһимовның татар теле белеме һәм әдәбияты, Н.Вәлишин һәм Г.Хәбировның арифметика, Ф.Сәйфи-Казанлы, Г.Фәхретдиновның тарих дәреслекләре һәм уку ярдәмлекләре; Г.Исхакый, Г.Баттал, Ә.Максуди, Ф.Туйкин, Р.Фәхретдинов һ.б.ның фәнни хезмәтләре, татар матур әдәбияты әсәрләре) бар. 1921 дә ширкәт национализацияләнә.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; шул ук. Становление и развитие татарской советской книги (1917–1932). К., 1989; Габдельганеева Г.Г. Полиграфия и печать в Казанской губернии. 1800–1917 гг. К., 2005; шул ук. Книжная торговля в Казанской губернии: вторая половина XVIII в. – 1917 г. К., 2006.

*Г.Г.Габделганиева.*



Г.С. Сабирҗанов.



Гомәр С. Сабирҗанов.

**САБЕ́РОВА** (Сабирова) Гөлзада Гарәфетдин кызы (1.1.1948, Балтач р-ны Кенәбаш а.), тел галиме, филол. фән. канд. (1995). 1971 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1973–76 да Респ-ка балалар китапханәсендә китапханәче булып эшли. 1977 дән ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында (2004–06 да директор урынбасары). Хезмәтләре терминология һәм татар теле лексикографиясенә карый. «Урман хуҗалыгында эшләүчеләр өчен русча-татарча сүзлекчә» («Русско-татарский словарь-минимум для работников лесной промышленности», 1997), «Үсемлекләр атамаларының татарча-русча-латинча сүзлеге» («Татарско-русско-латинский словарь названий растений», 2002), «Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге» (2013), «Русча-татарча актуаль лексика сүзлеге» (2004) һ.б.ның төзүче.

Х е з м.: Названия растений в татарском литературном языке. К., 1996; Татарско-русский словарь идиом. К., 2006 (автордаш).

**САБИ́Р** (чын исеме Мирза Алекпер оглы Таирзадә) (30.5.1862, хәзер Әзәрбайҗан Респ-касы Шәмәхә ш. — 1911, Баку ш.), әзәрбайҗан сатирик шагыйре. 1874 елдан мәгърифәтче, сатирик-шагыйрь С.А.Ширвани ачкан җәдиди мәдрәсәдә укый (Көньяк-Көнчыгыш Әзәрбайҗан). Ике елдан соң укуын ташларга мәҗбүр була. Үз кибетләрендә эшли. 1880 елларда, хаҗ кылуны сәбәп итеп, Кавказ артына, Гыйрак, Иран, Урта Азиягә сәяхәт кыла. Әтисенең вафатыннан соң Шәмәхәгә кайта. 1903–05 тә әзәрбайҗан газета-журналларында хезмәттәшлек итә. Гомеренең соңгы елларында Бакуда яши, укыта. Фәкыйрьлектә үлә. Әзәрбайҗан реалистик әдәбиятында сатира мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Иҗатының башлангыч чорында лирик шигырьләр, элегияләр яза. Татар укучылары арасында яратып укыла торган «Молла Насретдин» (Баку) сатирик ж-лының даими авторы сыйфатында танылa. Сәнгать чараларын киң кулланып, С. социаль типлар галереясын (халык һәм милләт мәнфәгатьләрен санламаучы, надан, сатлык, саран, рухи торгынлык изләрен) тудыра. С.ның «Шикаять» сатирасына Г.Тукай «Мулланың зары» (1908) исемле шигъри *назыйрә* яза. Г.Тукай шагыйрьне дәвалау өчен акча җыюда катнаша. С.ның дини рухтагы аерым шигырьләре 20 йөз башы татар матбугатында басылып чыга. 1985 тә С. шигырьләре Ә.Исхак тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителә.

*Әд.:* Ш а р и ф А. Жизнь и поэтическое творчество Сабира (1862–1911). М., 1951; З а м а н о в А. Сабир вә муасирләри. Бакы, 1973.

**САБИРҖА́Н АКЫ́Н** (чын исеме Сабирҗан Мөхәммәдсадыйк угылы) (19.7.1878, Казан губ. Олы Мәңгәр а. — 1922 елдан соң), шагыйрь. Казакъ телендә яза, татар лексикасын куллана. Яшь чагында казакъ далаларына китеп, тире иләү, тегү б-н көн күрә, казакъ халкының телен, традицияләрен, фольклорын өйрәнә. Берничә мәртәбә туган ягына сәяхәт кыла (соңгысы 1922 дә). Акыннар ярышында катнаша, шагыйрь-импровизатор буларак дан казана. Казакъ халкының 19 йөз ахыры — 20 йөз башындагы тормыш-көнкүреше, йола-традицияләре чагылдырылган «Жумбак казакъ телендә» (1903), «Кызның үләңе» (1903), «Тирмә казакъныкы» (1903), «Казакъның туй бәетләре» (1912) китаплары авторы.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М. Сабирҗан акын // Казан утлары. 1992. № 2.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**САБИРҖА́НОВ** Айдар Назим улы (18.7.1964, Казан), термофизик, техник фән. д-ры (2001), проф. (2004). 1986 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук, җылылык техникасының теоретик нигезләре кафедрасында эшли, проф. (2002 дән), бер үк вакытта Өстәмә проф. белем бирү ин-тының директор урынбасары (2005 тән). Хезмәтләре критик ноктаның киң диапазонында бер һәм күп компонентлы системаларның термофизик үзлекләренә, югары басым астында фазалар тигезләнешенә, үтә критик технологияләргә карый. С. оптик үтә күренмәле газ һәм сыеклыкларның җылылык һәм темп-ра үткәрүчәнлеген тикшерә; сыеклык һәм үтә критик флюид системасындагы парга аз әйләнүчән матдәләрнең үзара эрүчәнлеген фаразлау һәм аларның фазада таралу коэффициентын билгеләү өчен энтропик охшашлык алымын эшли.

Х е з м.: Обобщение бинарной растворимости низколетучих жидкостей в сверхкритических флюидах // Теорет. основы хим. технологии. 2001. Т. 35, № 2 (автордаш); Фазовые равновесия триэтиленгликоля и тетраэтиленгликоля со сверхкритическим пропаном // Теорет. основы хим. технологии. 2001. Т. 35, № 6 (автордаш); Суб- и сверхкритические флюиды в процессах переработки полимеров. К., 2007 (автордаш).

**САБИРҖА́НОВ** Габдулла Сабирҗан улы (26.10.1900, Сембер губ., Буа өязе Мөчәли а. — 24.2.1973, Куйбышев өлкәсенең Отрадный ш.), нефтьче, Соц. Хезмәт Герое (1948). 1917–21 елларда Кызыл Армиядә хезмәт итә, Гражданнар сугышында катнаша. Хезмәт эшчәнлеген 1921 дә «Грознефть» нефть чыгару идарәсендә бораулаучы булып башлый. 1929 дан «Сызраньнефть» бораулау конторасында эшли, 1939 дан Ставрополь нефть разведкасында, 1949 дан «Куйбышевнефтеразведка» трестының 2 нче турбиналы бораулау конторасында, 1954–57 дә «Куйбышевнефть» ҖБнең «Первомайнефть» тресты нефть промыселларында. Бораулау конторасындагы барлык катнаш белгечлекләрне өйрәнә. 1950 елларда, беренчеләрдән булып, скважинаны забойны су б-н юдырып көч кулланулы-тизлекле режимда бораулый, шуның нәтиҗәсендә бораулау тизлеге 2,4 тапкыр, хезмәт җитештерүчәнлеге 50% ка арта, шактый чыгымнар экономияләүгә ирешелә. С. җитәкләгән бригада ай саен җитештерү планын арттырып үти, квалификацияле бораулаучылар әзерләү мәктәбенә әйләнә. Чимкент (Казакъстан ССР), Оренбург, Чусовские городки (Пермь өлкәсе), Мухановск, Жигулёвск, Сызрань (Куйбышев өлкәсе) нефть чыганакларын ачуда һәм үзләштерүдә катнаша. Герой исеме нефть чыгаруда, яңа нефть чыганакларын һәм нефть скважиналарын бораулауда ирешкән уңышлары өчен бирелә: КПССның 20 нче съезды делегаты. Ике Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Отрадный шәһәренең Мактаулы гражданы; бер урам аның исеме б-н атала, С. яшәгән йортка мемориаль такта куелган.

*Әд.:* Б а х н и ц к и й С. Они добывают нефть: Рассказы о промыслах «Ставропольнефти» и их лучших людях. Куйбышев, 1948.

**САБИРҖА́НОВ** Гомәр Салих улы (20.4.1933, хәзер Самара өлкәсенең Кошки р-ны Яңа Фәйзулла а.), тарихчы, тарих фән. канд. (1971), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1983), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2008). ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тын оештыручыларның һәм җитәкчеләренең берсе. Ульянов пед. ин-тын (1955), КПСС ҮК каршындагы иҗтимагый фәннәр академиясен (Мәскәү, 1971) тәмамлый. 1955 елдан Тува автономияле өлкәсе Кызыл шәһәренең халык мәгарифе системасында: тарих укытучысы, мәктәп-интернатның уку-укыту бүлеге мөдире, халык мәгарифенең шәһәр бүлеге мөдире. 1961 дән Кызыл шәһәрендә партия эшендә: шәһәр ком-тының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире, КПССның Тува өлкә ком-ты 1 нче секретаре ярдәмчесе, идеология бүлеге мөдире урынбасары (1963 тән), КПСС өлкә ком-тының мәктәпләр һәм уку йортлары бүлеге мөдире (1965–68). 1971–80 дә ТАССР МС Эшләр идарәсенең социаль-мәдәни оешмалар бүлеге мөдире (бүлек халык мәгарифе, мәдәният, социаль тәэминат, сәламәтлек саклау министрлыклары, физик тәрбия һәм спорт ком-тлары, матбугат, дарухanә идарәләре, архив идарәсе эшчәнлегенә күзәтчелек итә). 1980–92 дә Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тының тарих һәм мәдәният теориясе кафедрасын оештыручы һәм мөдире. 1992 дән ТР ФАнең Татар энциклопедиясе бүлеге мөдире, 1994–2011 дә ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-ты директоры урынбасары, 2011 дән баш мөхәррире урынбасары, күптомлы Татар энциклопедиясенең җаваплы мөхәррире. Хезмәтләре СССР халыкларының Бөек Ватан сугышы елларында һәм сугыштан соңгы халык хуҗалыгын торгызу чорында мәдәни төзелеш өлкәсендә үзара ярдәмләшүе, сугыштан соңгы елларда халык хуҗалыгын торгызуы, Урта Идел буе һәм Көньяк Урал төбәге халыкларының социаль-мәдәни үсеше тарихына, бу өлкәләрдәге милләтара мөнәсәбәтләр тарихын гыйльми өйрәнүгә карый. Рус һәм татар телләрендә Татар энциклопедия сүзлеген эшләүгә һәм нәшер итүгә керткән өлеше өчен ТРның Дәүләт бүләгенә лаек бу-

ла (2005). «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Партийное руководство народным образованием в Советской Туве (1944–1967 гг.). Кызыл, 1967; Сотрудничество народов СССР в подготовке кадров национальной интеллигенции в 1945–1950 гг. // История СССР. 1971. № 3; По законам дружбы и братства: Взаимная помощь народов СССР в культурном строительстве в годы Великой Отечественной войны и послевоенного восстановления народного хозяйства (1941–1950 гг.). К., 1974; Поволжские татары и русские в зеркале симпатий и антипатий. К., 1993; Народы Среднего Поволжья и Южного Урала в панораме веков. К., 1999.

*Әд.:* Казанский государственный университет культуры и искусств. 1964–2004 гг.: Краткая история. К., 2004.

**САБИРҖА́НОВ** Нургали Сабирҗан улы (1.1.1927, хәзер Буа р-ны Иске Суыксу а. — 23.7.2010, шунда ук), агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. а.х. хезмәткәре (1985). Колхоз рәисләрен әзерләүче Татарстан урта а.х. мәктәбен тәмамлый (Казан, 1956). 1941–88 елларда Буа р-ның «Татарстан» к-зында эшли: ферма мөдире (1951 дән), агроном (1954 тән), рәис (1959 дан). С. җитәкчелегендә хуҗалык Татарстанда иң алдынгыларның берсенә әверелә, Ленин ордены б-н бүләкләнә. Бөртекле ашлыкны уртача еллык җитештерү күләме 7,5–9 мең *т*, шикәр чөгендере — 10–12,5 мең *т*, сөт — 1,7–1,9 мең *т*, ит — 360 *т* тәшкил итә. 100 *га* а.х. җирләренә 270–300 *ц* сөт, 57 *ц* ит җитештерелә. Бөртекле ашлык уңышы 1 *га* дан 25–30 *ц* га, еллык савым һәр сыердан уртача — 2700–3000 *кг* га җитә. Хуҗалыкның табышлылык дәрәҗәсе 76–85% тәшкил итә. Колхозчыларның 3 нче Бөтенсоюз съезды делегаты (1969). 1971–75 тә ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**САБИ́РОВ** Айрат Мансур улы (28.11.1965, Буа р-ны Кырык Садак а.), галим агроном, а.х. фән. д-ры (2003), проф. (2008). 1990 елда Казан а.х. ин-тын (хәзер Казан аграр ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, экология һәм табигый байлыклардан файдалану каф. мөдире (2004 тән). Хезмәтләре үсемлекләрнең продуктлылыгына ашламаларның тәэсирен, агач токымнарның үсентеләре һәм чәчкеннәре үсешен өйрәнүгә карый. Уйлап табуга патентлы бар.

Х е з м.: Ресурсосберегающие технологии и экономические нормативы производства продукции растениеводства в условиях Республики Татарстан. К., 2002 (автордаш); Экология: Учеб. пособие. К., 2005.

**САБИ́РОВ** Айрат Таһирҗан улы (28.9.1962, Арча р-ны Яңа Иябаш а.), туфрак белгече, биол. фән. д-ры (2000), проф. (2002). Мари политехник ин-тын тәмамлый (1985). 1986–2000 елларда Мари техник ун-тында укыта. 2000 нән Казан аграр ун-тында, таксация һәм урман хуҗалыгы каф. мөдире, урман хуҗалыгы һәм экология ф-ты деканы (2004 кә кадәр), бер үк вакытта проректор (2004–08). Хезмәтләре урман туфраклары үзлекләре һәм генезисына, урман җирләре экологиясе һәм мониторингына карый. Урта Идел буе урман экосистемаларының биотөрлелеген һәм продукт бирүчәнлеген, ТРның Кама һәм Идел алдындагы саклаучы урман туфракларын тасвирлый.

Х е з м.: Соединения оксидов железа в основных типах лесных почв Среднего Поволжья // Почвоведение. 1991. № 3 (автордаш); Содержание подвижных микроэлементов в почвах тёмнохвойных биогеоценозов // Экология и леса Поволжья. Йошкар-Ола, 1999; Почвенно-экологические условия произрастания еловых и пихтовых фитоценозов Среднего Поволжья. К., 2001 (автордаш).

**САБИ́РОВ** Альянс Бәдри улы (1.5.1944, Азнакай р-ны Тымытык а.), журналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). 1962 елда Лубян урман техникумын, 1977 дә Казан ун-тын тәмамлый. «Волжская правда» (1968 дән), «Советская Татария» (1970 тән) г-таларында эшли, Татарстан, Мари, Удмурт респ-калары буенча «Известия» г-тасының үзхәбәрчесе (1975 тән), «Татинком» компаниясе ген. директоры (1992 дән), «Бан-Корп» корпорациясе һәм «Идел-Урал Телеком» ҖЧҖнең төбәк ассоциациясе директорлар советы рәисе (1994 тән). «Идел-Урал» мәгълүмат агентлыгы шеф-мөхәррире (1994 тән). Илнең иҗтимагый-сәяси проблемаларына, икътисади үсешенә, КамАЗ һәм Татарстанның башка төзелешләрендәге хезмәт алдынгыларына, алдынгы тәҗрибәне куллану һәм ярыш хәрәкәтенең башка мәсьәләләренә, авылның иҗтимагый һәм мәдәни тормышын үстерүгә багышланган хезмәтләр авторы. «Шәрекъ гыйлеме халык китапханәсе» («Народная библиотека востоковедения») Хәйрия фонды рәисе. Респ-ка Журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. бүләге лауреаты (1975), СССР Журналистлар берлеге бүләге лауреаты (1979).

Х е з м.: Москва–Сибирь–Тихий океан. М., 1978; Нижнекамские зарисовки. К., 1996; Менделеевские самоцветы. К., 1998; Ровесник века. К., 2001.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**САБИ́РОВ** Әсхәдулла Галимҗан улы (24.5.1954, Удмурт АССРның Можга р-ны Можга ш.), философ, филос. фән. д-ры (1998), проф. (1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), Алабуга пед. ин-тында, филос. һәм социол. каф. мөдире (1983 елдан). Хезмәтләре социаль философиягә һәм антропологиягә, мәгариф философиясенә карый.

Х е з м.: Социально-философская антропология: принципы конструирования и предметного определения. М., 1997; Татарская философия: сущность, история, роль в духовном развитии татарского народа. Елабуга, 2012; Русский человек: сущность, своеобразие и перспективы развития. К., 2014.

**САБИ́РОВ** Гази Сабир улы (31.12.1912, Казан губ., Цивильск өязе Чүти а. — 17.11.1994, Ташкент), хакимият-хуҗалык җитәкчесе. 1946–65 елларда Фирганә монтаж идарәсе башлыгы. 1965–78 дә Үзбәкстан ССРның монтаж һәм махсус төзелеш эшләре министры. Каналлар һәм таулардагы тарлавыклар арасында асылма күперләр эшләү остасы. Нефть химиясе аппаратларын эретеп ябыштыру өчен манипулятор (1962), сферик резервуарларны вальцовка алымы б-н күпләп җитештерү җайланмасы (1964) уйлап табып гамәлгә куючыларның берсе.

**САБИ́РОВ** Ирек Нәгыйм улы (14.4.1950, Биектау р-ны Мәмдәл а.), хакимият-хуҗалык җитәкчесе, шагыйрь, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2008). Татар һәм рус телләрендә иҗат итә. Казан химия-технол. ин-тын тәмамлагач (1973), Чиләбе өлкәсенең Еманжелинск шәһәрендә урнашкан «Сигнал-полимер» з-дына эшкә җибәрелә. Биредә ул мастердан цех начальнигы, баш инженер дәрәҗәсенә кадәр хезмәт юлы уза. 1999 дан шәһәр башлыгы урынбасары. С. «Аваз» (Чиләбе, 1999), «Манзара» (2004), «Ләззәт ташкыны» (2010), рус телендә «Люблю и верю» (Челябинск, 1997), «Сезон клубники и зарниц» (Еманжелинск, 1998), «Апрель» (Еманжелинск, 2002), «Предчувствую весну» (Еманжелинск, 2008) шигырь җыентыклары авторы. 1989 дан Еманжелинск шәһәрендә Татар һәм башкорт мәдәнияте үзәге идарәсе рәисе. 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орден медале б-н бүләкләнә.


**САБИ́РОВ** Каюм Сабир улы (15.11.1922, Арча кантоны Бишнә а. — 19.8.1979, Казан), тел галиме, филол. фән. канд. (1957). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында эшли. Хезмәтләре татар теле лексикологиясе, фонетикасы, пунктуациясенә карый. Аның «Татар теле лексикологиясе» («Лексикология татарского языка») хезмәте югары уку йортлары өчен татар (1966) һәм рус (1969) телләрендә нәшер ителгән «Хәзерге татар әдәби теле» («Современный татарский литературный язык») дәреслегенә аерым бер бүлек буларак кертелгән. «Русча-татарча сүзлек»нең (3 т., 1958) автордашы. В.Н.Хангилдинның татар тел белеменә караган «Татар теле грамматикасы» (1959), өч томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (1977–81) кебек берничә зур хезмәтнең фәнни мөхәррире. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Татар теленең тыныш билгеләре. К., 1956; Татар телендә тыныш билгеләре кагыйдәләре. К., 1963.

**САБИ́РОВ** Мөхәммәт Галләм улы (29.3.1932, БАССРның Кушнаренко р-ны Яңа Кормаш а. — 9.3.2015, Казан), дәүләт эшлеклесе, тау инженеры, РСФСР Ягулык һәм энергетика министрлыгының атказ. хезмәткәре (1980), СССР Нефть төзелеше министрлыгы отличнигы (1978), ТАССРның атказ. төзүчесе (1983). «Нефть һәм газ скважиналарын бораулау» белгечлеге буенча Уфа нефть ин-тын (1955), СССР Халык хуҗалыгы академиясенең Халык хуҗалыгы б-н идарә итү ин-тын (1983) тәмамлый. 1955–65 елларда «Әлмәтбораулаунефть» трестында: 2 нче бораулау конторасында бораулаучы ярдәмчесе, инженер, өлкән инженер, бүлек башлыгы урынбасары (1960–64), партком секретаре (1964 тән). КПССның Әлмәт шәһәр ком-ты 2 нче секретаре (1965–68). 1968–81 дә «Востокмонтажгаз» (Әлмәт ш.) тресты башлыгы. 1971 дә Уренгой–Помары–Ужгород газүт-



М.Г. Сабиров.



Р.Ә. Сабиров.

кәргеченең Төмән өлкәсендәге 75 километрлы участогын салуда трестның уңышлы хезмәте өчен Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. 1969 ның ноябрендә трестка Оренбург газ конденсаты чыганагын җиһазландыру йөкләнә. Бер үк вакытта, 1979 дан, С. Шибирган провинциясендә Әфганстан–СССР газүткәргечен салу эшләре б-н җитәкчелек итә (1980 дә икенче Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә). 1981–84 тә «Татнефтестрой» җитештерү берләшмәсе җитәкчесе. 1984–89 да ТАССР МС рәисе урынбасары, 1989–91 дә — рәисе, 1991–95 тә ТР Премьер-министры.

Респ-каның нефть сәнәгате үсешенә, нефтьчеләрнең яшәү шартларын яхшыртуга, мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуга зур өлеш кертә. С. ТАССР МС рәисе урынбасары вазифасын башкарган дәвердә Татарстанда юллар, күперләр төзү программасы тормышка ашырыла, Займище тимер юл станциясе янында Идел аша автомобиль күпере (1989), нефть химиясе объектлары, КамАЗ пр-тиеләре комплексы төзелеше тәмамлана. С. ТАССР МС рәисе һәм ТР Премьер-министры булып эшләгән елларда иҗтимагый-сәяси һәм социаль-икътисади стройның асылын тамырдан үзгәртеп кору шартларында хакимият тарафыннан сәнәгать, а.х. секторы, сәүдә системасы, социаль-мәдәни блок оешмалары һәм учреждениеләренең җитештерү эшчәнлеген тәэмин итү буенча чаралар, авылларга газ кертү программасы башкарыла, автомобиль юллары төзелә, Саескан тавы янында Кама елгасы аша күпер төзелеше башлана. РСФСР ЮС депутаты сыйфатында С. Советлар чорыннан соңгы Россиядә дәүләт төзелеше мәсьәләләре буенча карарлар кабул итү һәм фикерләшүдә катнаша (РСФСР Конституциясенең 6 нчы һәм 7 нче маддәләрен гамәлдән чыгару һ.б.). 1990 ның августында «*Татарстан Совет Социалистик Республикасының Дәүләт суверенитеты турында декларация*»не әзерләүдә һәм кабул итүдә катнаша; 1994 нең 15 февралендә РФ Президенты Б.Н.Ельцин, РФ хөкүмәте рәисе В.С.Черномырдин, ТР Президенты М.Ш.Шәймиев б-н бергә «*Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында шартнамә*»гә кул куя. В.С.Черномырдин һәм С. ТРда хәрби төзелеш, хәрби-сәнәгать комплексы, бюджет, таможня, финанс, нефть, ТРның тышкы икътисади эшчәнлеге һ.б. турындагы хакимиятара килешүләргә шартнамә нигезендә кул куялар. ТР ФАне, ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тын, Бөтендөнья татар конгрессын (беренче корылтаен уздыру буенча оештыру ком-ты рәисе) булдыруда актив катнаша.

1985–90 да ТАССР, 1990–95 тә РСФСР ЮС депутаты; РФ Дәүләт Думасында автономияле респ-калардан сайланган депутатлар төркеме җитәкчесе; 1995–2000 дә ТРның халык депутаты, ТР Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы (1999 га кадәр). 1994–95 тә РФ Федераль Җыенының Федерация Советы әгъзасы. 2000 нән «Туган җир» Татарстан халыклары тарихи-мәдәни мирасы респ-ка иҗтимагый фонды президенты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе», Дуслык, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Термообработка сварных соединений в полевых условиях. Альметьевск, 1979; Основные направления экономического и социального развития Республики Татарстан в соответствии с новой Конституцией Республики Татарстан. К., 1980; Три поры: Воспоминания, выступления, интервью. К., 2006; Строители нефтяного края. К., 2008.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**САБИ́РОВ** Наил Закир улы (22.8.1932, Әтнә р-ны Дусым а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1983). Казан ун-тын тәмамлый (1963). Түбән Көек (1950 дән) һәм Ары (Ислетар) (1952 дән) мәктәпләрендә укыта, ВЛКСМның Әтнә район ком-ты оештыру бүлеге мөдире (1954), 2 нче (1954 тән), 1 нче (1957 дән) секретаре; 1980–93 тә «Чулпан» к-зы рәисе, 1994 тән Әтнә р-нында агросәнәгать комплексы хезмәткәрләре профсоюзының район ком-ты рәисе. 2002 дән «Арчанефтепродукт» АҖнең а.х. буенча ген. директор киңәшчесе. С. җитәкче булганда, «Чулпан» к-зында барлык җитештерү объектлары, социаль-мәдәният һәм көнкүреш биналары яңартыла һәм төзелә, хуҗалыкка һәм торак пунктларга газ һәм телефон кертелә; бөртекле ашлык җитештерү — 2,3, бәрәңге — 2,8, сөт — 4,7, ит җитештерү 3,2 тапкыр арта, бөртеклеләр һәм бөртекле-кузаклы культураларның уңышы — 1 *га* дан 7,56 *ц* дан — 25,7 *ц* га, бәрәңгенеке 51,5 *ц* га арта. 1983 тә колхоз КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. 1985–90 да ТАССР ЮС депутаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**САБИ́РОВ** Рафаэль Шакирҗан улы (24.3.1951, Теләче р-ны Үзәк пос.), галим агроном, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004), ТРның атказ. агрономы (1993). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), Теләче р-нында: Ленин исем. тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгында (1984 тән) һәм «Агрофирма «Вамин-Теләче» ҖЧҖдә (2006 дан) агроном-орлыкчылык белгече, баш агроном. Дәүләт бүләге хуҗалыкта терлек азыгы җитештерүнең заманча системасын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**САБИ́РОВ** Рәис Мәрдан улы (1.2.1927, Дөбъяз р-ны Ташсу а. — 15.12.2010, Казан), журналист, публицист, ТАССР һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1977, 1988). Казан хокук ин-тын (1952), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1956) тәмамлый. 1949–52 елларда «Яшь сталинчы» г-тасында тәрҗемәче, бүлек мөдире, баш мөхәррир урынбасары булып эшли. 1952–53 тә КПССның Татарстан өлкә ком-тында пропаганда һәм агитация бүлеге инструкторы. 1956 дан «Совет Татарстаны» г-тасының әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире, 1958 дән «Правда» г-тасының ТАССР һәм Мари АССР буенча үзхәбәрчесе, 1983 тән «Социалистик Татарстан» г-тасы баш мөхәррире. 1990–94 тә ТР Министрлар Кабинетының баш референты. СССРның әйдәп баручы басма органнарының берсе булган «Правда» г-тасының үзхәбәрчесе булып эшли. Татарстанның иҗтимагый-сәяси һәм социаль-икътисади үсешенә караган төп мәсьәләләр буенча мәкаләләр һәм очерклар б-н чыгыш ясый, КамАЗ, Казан органик синтез з-ды төзелешенә, мәгариф, фән һәм мәдәният системаларын үстерү проблемаларына зур игътибар бирә. Украина язучысы М.А.Стельмахның «Кеше каны җирдә ятмас» («Кровь людская — не водица», 1962) романын, казакъ язучысы С.М.Мукановның «Тормыш мәктәбе» («Школа жизни», 1962) автобиографик повестен, В.И.Ленин һәм совет сәяси әдәбияты әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. 1985–90 елларда ТАССР ЮС депутаты. ТАССР Журналистлар берлеге рәисе (1983–84). Респ-ка Журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. бүләге лауреаты (1971). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Кара алтын чишмәсе. К., 1971 (автордаш); К сокровищам земли. К., 1968; По городам Татарии: Путеводитель. К., 1976.

*Әд.:* «Правда» и Татария. К., 1982.

**САБИ́РОВ** Рәүф Әхмәтсабир улы (1.12.1894, Казан губ., Мамадыш өязе Айдар а. — 30.12.1937, Казан), дәүләт эшлеклесе. Түбән Новгород шәһәрендә заводта күмер ташучы, Бахмут шәһәре (Екатеринославль губ.) тирәсендәге тоз чыганакларында бораулаучы булып эшли. 1915 елда Россия армиясенә алына; Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1918 дә Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең икенче корылтае делегаты (Казан). Соңыннан Мамадыш башкарма ком-ты рәисе. 1921–24 тә ТАССР ҮБК Президиумы рәисе. «*Унбиш җитәкче хаты*» авторларының берсе (1923). Хатта М.Солтангалиевне кулга алуның гаделлегенә шик белдерелә һәм РКП(б)ның 12 съездында милли мәсьәлә буенча кабул ителгән карарның үтәлешендә җитди хаталар булуы бәян ителә. 1924 тә «*Утыз тугыз җитәкче хаты*»на кул куя. Хатта татар коммунистларына кимсетеп карау фактлары күрсәтелә, Татарстан партия оешмасында үзара килешмәүчәнлеккә һәм низагларга чик кую чаралары тәкъдим ителә. Респ-каның башка җитәкчеләре б-н беррәттән, милләтчелектә гаепләнеп, Мәскәүгә, түбәнрәк дәрәҗәле эшкә күчерелә, Бөтенроссия ҮБКның милли бүлеге мөдире урынбасары

итеп билгеләнә (1925). 1929 да «Солтангалиевнең партиягә каршы төркеме»ндә катнашуда гаепләнеп партиядән чыгарыла. 1932 дән «ЗИС» Мәскәү автомобиль з-дында фрезерчы, станоклар төзәтүче, бригадир булып эшли. «Татреспублика авылы ачлыктан соң» («Деревня Татреспублики после голода», 1923) китабы авторы. Репрессияләр корбаны.

*Әд.:* Султанбеков Б. Сабиров Рауф Ахметович // Возвращённые имена: Док. очерки. К., 1990.

**САБИ́РОВ** Рәшит Хафиз улы (6.7.1955, Норлат р-ны Бәчек а.), эстрада артисты, нәфис сүз остасы, ТССРның халык артисты (1991). Казан театр уч-щесен (1976), Казан ун-тын (1982) тәмамлый, 1976 елдан сөйләм жанры артисты булып эшли, Татар филармониясендә концерт программалары алып бара. Аудиторияне яхшы тоюы, импровизация осталыгы, сәхнәдәге мөлаемлыгы, концерт материалын биргәндә үзен иркен һәм табигый тотуы С.ка тамашачы б-н җылы, дустанә мөнәсәбәт урнаштырырга ярдәм итә. Артист репертуарын Г.Тукай, Һ.Такташ, Х.Туфан, М.Җәлил, А.Алиш, Ф.Кәрим, С.Хәким, Г.Афзал, Ф.Шәфигуллин, Ф.Яруллин, Г.Зәйнашева әсәрләре тәшкил итә. Аның башкаруы югары сөйләм культурасына, поэтик фикернең төсмерләр байлыгын бөтен нечкәлекләре б-н җиткерә белү сәләтенә, нечкә юмор хисенә ия булуы ягыннан аерылып тора.

**САБИ́РОВ** Ринат Касыйм улы (26.7.1967, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008), химия фән. канд. (1995). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1991), Казан технол. ун-тында эшли. 1996–2003 елларда «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖдә баш белгеч, маркетинг бүлеге башлыгы. 2003–10 да МКда, ТР Премьер-министрының нефть-газ комплексы мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, киңәшчесе. 2010 нан ТР Президенты ярдәмчесе. Дәүләт бүләге ТРда җитештерелгән зур тонналы полимерлар нигезендә динамик термоэластопластлар — яңа буын композицион материаллар җитештерүне оештыруда һәм эшләүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**САБИ́РОВ** Ринат Сабир улы (18.1.1953, Арча р-ны Күлтәс а. — 27.7.2004, шунда ук), галим агроном, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995), ТАССРның атказ. агрономы (1985). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1975), Арча р-нында эшли: «Сортсемовощ» районара бүлегендә агроном, «Известия» к-зында (1976 дан), «Казанбаш» агрофирмасында (2003–04) баш агроном. Дәүләт бүләге җитештерүдә фән һәм техника казанышларын киң куллану нигезендә бөртекле культуралардан югары уңыш алганы өчен бирелә.

**САБИ́РОВ** Рөстәм Рәис улы (13.12.1951, Казан), язучы. Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1973). 1975–82 елларда Казан язу машиналары з-дында, 1982–84 тә — «Радиоприбор» з-дында икътисадчы, Татарстан китап нәшриятында (1984–92) мөхәррир, 1992 дән ТР ЮСның редакция-нәшрият бүлегендә баш белгеч булып эшли. Рус телендә яза. «Фәрештә белән хушлашу» («Прощание с ангелом», 1991), «Сәер вакыйгалар. Очучы Голланд» («Странные истории. Летучий Голландец», 1998), «Лабиринтның ахыры» («Конец лабиринта», 2001), «Качкын» («Беглец», 2007) хикәя һәм повесть җыентыклары авторы. С. әсәрләрендә фантазия һәм гротеск көндәлек вакыйгалар б-н үрелеп бара. Автор борынгы грек мифлары темаларына, тарихи фантазияләргә, ирекле трактовкаларга мөрәҗәгать итә.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**САБИ́РОВ** (Нәзыйров) Сафа Сабир улы (19.8.1915, Казан губ., Лаеш өязе Иске Йорт а. — 29.3.2004, Казан), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1986). Балалар йортында тәрбияләнә. ФЗӨ мәктәбендә укый, Казан елга техникумын тәмамлый (1938). 1947–54 елларда Идел пароходчылыгының Казан бүлекчәсендә диспетчер. 1954 тән «Социалистик Татарстан» г-тасында күчмә хәбәрче. 1957–75 тә Татарстан китап нәшриятында: матур әдәбият редакциясе мөдире, 1971 дән өлкән мөхәррир. С.ның беренче хикәяләре 1945 тә «Совет әдәбияты» ж-лында басылып чыга. 1949 да нахимовчыларга багышланган беренче повесте — «Яшь диңгезчеләр» дөнья күрә. Елга транспорты хезмәтчәннәренең эшен һәм тормышын яктырткан «Дүрт елга буйлап» (1951; рус теленә тәрҗемәдә «По четырем рекам», 1952), «Зур Идел туганда» (1952), «Су өстендә акчарлак» (1966), «Идел җилләре» (1975), «Җил тулсын җилкәннәргә» (1981), «Идел йолдызлыгы» (1996) һ.б. повесть, хикәя һәм очерклар җыентыклары авторы. «Хатлар язам сагынып» (1982) һәм «Хәвефле сәфәр» (1995) тарихи повестьларының төп геройлары — үзләренең романтик һөнәрләренә гашыйк яшь капитаннар. С.ның кайбер әсәрләре рус һәм чуаш телләренә тәрҗемә ителгән. Бөек Ватан сугышында катнаша, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Алтын балдаклы абыстай. К., 2004.

*Әд.:* Әгъләм М. Үз заманы баласы // Казан утлары. 2000. № 8; Кәримов К. Иске Йорт аксакалы // Казан утлары. 2005. № 7.

*Г.М.Габделхакова.*

**САБИ́РОВ** Фәйзерахман Әхмәтҗан улы (5.9.1919, хәзер Киров өлкәсенең Вятка Аланы р-ны Яңа Шөн а. — ?), Сов. Союзы Герое (19.4.1945), полковник. Камышлов хәрби пехота уч-щесен (Свердловск өлкәсе, 1941), «Выстрел» курсларын (Мәскәү өлкәсенең Солнечногорск ш.) тәмамлый. 1938–40 елларда һәм 1941 дән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 771 нче укчы полкта батальон командиры (48 нче армиянең 137 нче укчы дивизиясе). Брянск, Үзәк һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Елец һәм Малоархангельск юнәлешләрендәге сугышларда (1943), Курск сугышында (1943), Белоруссия (1944) һәм Көнчыгыш Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Польша терр-ясендәге Клаин һәм Раутенберг сугышларында батырлык күрсәтә: 1945 нең 30 гыйнварыннан 2 февраленә кадәр С. җитәкчелегендәге батальон дошманның күпләгән һөҗүмнәрен кире кайтара. Дошман чолгап алган өйдә 8 сугышчы б-н калгач, С. шәхсән үзе 2 танкны сафтан чыгара; совет артиллериясеннән үз өстенә 5 тапкыр ут ачтыра, әмма батальон б-н җитәкчелеген дәвам итә. Сугыштан соң Совет Армиясе сафларында хезмәттә кала. 1976 дан запаста. Мәскәү ун-тының гражданнар оборонасы штабында эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз, өч «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.



Р.Х.Сабиров.



Ф.Ә.Сабиров.

**САБИ́РОВ** Хафиз Сабир улы (1910, Вятка губ., Малмыж өязе Иске Торҗа а. — 5.3.1940, Виипури ш. тирәсе, хәзер Ленинград өлкәсе Выборг ш., Харяппян Ниеми борынында җирләнә), Сов. Союзы Герое (21.3.1940, үлгәннән соң), кече лейтенант. Командирлар составын камилләштерү фронт курсларын тәмамлый. Туган авылында колхозда эшли. 1932 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша, 169 нчы укчы полкның пулемёт взводы командиры (7 нче армиянең 86 нчы мотоукчы дивизиясе). Төньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре составында Тупуран-Саари посёлогы (Карелия муенты-гы) һәм Виипури шәһәре тирәсендәге сугышларда батырлык күрсәтә: 1940 ның 1–4 мартында дошманның җанлы көчләренә һәм техникасына зур зарар китерә; 5 мартта укчы батальонга чигенү юлын ышыклап, шул сугышта һәлак була. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**САБИ́РОВ** Шамил Алтай улы (4.4.1959, Свердловск өлкәсенең Карпинск ш.), спортчы (бокс), СССРның атказ. спорт остасы (1980), пед. фән. канд. (1987), бөтенсоюз категорияле судья (1991). Краснодар физик культура ин-тын тәмамлый. Спорт б-н 1975 елда шөгыльләнә башлый, «Труд» ирекле спорт җәмгыятендә чыгыш ясый (Краснодар ш.). СССР (1980, 1983), Европа (1979), Олимпия уеннары (1980) чемпионы, СССР халыклары Спартакиадасында җиңүче (1983); СССР чемпионатында (1978–79), СССР халыклары Спартакиадасында (1979), Европа чемпионатында (1981, 48 *кг* га кадәрле иң җиңел авырлыкта) бронза приз алучы. 1978–85 елларда СССР җыелма командасы составында 180 чыгыш ясый, 160 тапкыр җиңүче була. Краснодарда яши. 2006 дан Краснодар краеның «Бокс буенча спорт әзерлеге үзәге» дәүләт учреждениесе директоры. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**САБИ́РОВА** Дания Кыям кызы (20.5.1944, Лаеш р-ны Сиңгел а. – 15.7.2015, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1989), проф. (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994). РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2012). Казан ун-тын тәмамлый (1972). 1969–70 елларда Казан мед. ин-тының комсомол оешмасы секретаре, 1970–72 дә Казанның Киров р-ны Пионерлар йорты методисты. 1975 тән Казан техник ун-тында, тарих һәм җәмәгатьчелек б-н элемтәләр каф. мөдире (1990 нан), гуманитар ф-т деканы (1995 тән), Социаль технологияләр ин-ты директоры (2009–13). Бер үк вакытта Казан техник ун-ты каршындагы югары уку йортлары социаль-икътисад фәннәре укытучыларының белемнәрен күтәрү ин-ты директоры (1994 тән). Хезмәтләре эшчеләр сыйныфы, милләтара мөнәсәбәтләр тарихына карый. «Татарстан хезмәт ияләренең интернациональ элемтәләре» («Интернациональные связи трудящихся Татарии», 1989) документлар җыентыгын төзүче. Югары уку йортлары өчен Татарстан тарихы, 20 йөз сәяси тарихы, җәмәгатьчелек б-н элемтәләр фәне буенча дәреслекләр авторы. «XX йөз социаль-сәяси тарихы» («Социально-политическая история XX в.») уку ярдәмлеге өчен Бөтенроссия фәнни эшләр конкурсында лауреат исеменә лаек була (1990). ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Руководство КПСС развитием интернациональных связей рабочего класса СССР: История, опыт, проблемы. К., 1988.

*Әд.:* Д е г т я р ё в Г.Л., С а ф а р и е в М.С. Казанский государственный технический университет им. А.Н.Туполева: Люди и вехи истории. К., 2002; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**САБИ́РОВА** Диана Рөстәм кызы (15.7.1970, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (2010). Казан пед. ун-тын тәмамлый (1992). 1990 елдан Казанның 116 нчы урта мәктәбендә инглиз теле укыта. 1993 тән Казан пед. ун-тының (2005 тән — Татар гуманитар пед. ун-ты) инглиз теле һәм инглиз телен укыту методикасы кафедрасында, 1998 дән каф. мөдире. 2011 дән Казан ун-тында: Европа телләре һәм культуралары каф. мөдире. Бөекбританиядә пед. белем бирү тарихы һәм заманча укыту проблемалары буенча хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Профессиональное педагогическое образование в Англии: Последняя четверть XX в. К., 2006; Непрерывное педагогическое образование в Великобритании: Исторический аспект. К., 2007.

**САБИ́Т БОЛГАРИ́ ӘЛ-КАВАЛЫ́Й** (чын исем-фамилиясе Сабир Сәгыйтов) (1805, Казан губ., Казан өязе Олы Кавал а. — 1876, Тәтеш өязе Чирмешән а.), хаттат, китап күчереп язучы (насих). Мулла һәм хаттат Сәгыйть әл-Кавалый (1778–1862) гаиләсендә туа, Олы Кавал мәдрәсәсендә укый. 1841 дән Чирмешән авылындагы 1 нче Җамигъ мәчет имамы. ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында өч авторның: ахун Дамелла Фәхрелислам Вәлидетдин, Шәрәфетдин Әбү-Габдулла Мөхәммәт ибне Сәгыйт әл-Бусири, өченче авторның исеме күрсәтелмәгән — чәчмә һәм шигъри әсәрләренең С.Б.әл-К. тарафыннан күчерелгән гарәпчә кульязма җыентыгы саклана. Җыентык 1857 дә төзелгән. Китап алтынсу басма орнамент төшкән көрән күн б-н тышланган. Кульязма көрән төстәге шәрекъ кәгазендә (13,5×20,5 *см*) әзерләнгән. Текст (7,8×14,7 *см* форматлы һәр биттә 17 шәр юл) «нәстәгъликъ» язуы һәм кара тушь б-н язылган («с», «ш» хәрефләре «нәсех», «тәгъликъ» рәвешендә) һәм кырларга сирәк кенә өстәмәләр кертелгән. Исемнәр, өземтәләр һәм



Сабит Болгари әл-Кавалый. Әдәби әсәрләр җыентыгыннан бер бит. Кульязма. Кәгазь. Тушь. 1857. Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кульязмалар бүлеге.

билгеләр кызыл буяу б-н күрсәтелгән. Бит тәртибен саннар б-н күрсәтү шәрекъ стиленә туры килә (үткән бит ахырындагы соңгы сүз алдагы бит башында кабатлана), ул 18–19 йөзләр татар кульязмаларында еш очрый. *М.И.Әхмәтҗанов.*

**САБИ́ТОВ** Вил Хәйдәр улы (3.4.1937, Чистай ш. — 22.1.1997, Казан), инженер-механик, «Медицина нструментлары» фәнни-җитештерү пр-тиесе ген. директоры (1981–97), техник фән. канд. (1978), РСФСРның атказ. машина төзүчесе (1978). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), Казан компрессорлар з-дында инженер-конструктор булып эшли. 1961–63 елларда Татарстан ХХСда өлкән инженер. 1963–65 тә «Теплоприбор» үзәк проектлау-конструкторлык бюросында (Казан) бүлек башлыгы. 1965–71 дә Казан мед. инструментлары з-дында баш конструктор. 1971–81 дә Бөтенсоюз мед. инструментлары фәнни-тикшеренү һәм проектлау ин-ты директоры. С. җитәкчелегендә илдә беренче буларак стомат. өчен эшләнмәләр, офтальмология, нейрохирургия, йөрәк-кан тамырлары хирургиясе өчен инструментлар эшләнә. Уйлап табуга 30 дан артык авторлык таныклыгы бар. Халыклар дуслыгы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

**САБИ́ТОВ** Габделхәй Вәли улы (28.6.1931, Минзәлә р-ны Югары Тәкермән а. — 29.10.1995, Казан; Минзәлә шәһәрендә җирләнә), язучы. 1949–56 елларда Минзәлә р-ны урта мәктәпләрендә укытучы. 1956–60 та А.М.Горький исем. Әдәбият ин-тында (Мәскәү) укый. 1960–65 тә ТАССР МСның радиотапшырулар һәм телевидение ком-тында әдәби-драматик тапшырулар мөхәррире, «Ялкын» ж-лының әдәбият бүлеге мөдире. 1965 тән «Чаян» ж-лында, 1968 дән җаваплы сәркәтип. 1950 еллардан көндәлек матбугатта әсәрләре басылып килә. «Туган җир туфрагы» (1963), «Үлемсез Акылгали» (1964), «Тармаклы яшен» (1981), «Урман кызы» (1991), «Кайнар туфрак» (2001), «Ярсулы яз» (2002) исемле хикәя җыентыклары, «Кичерелмәс гөнаһ» (1959 да Минзәлә татар драма театрында куела), «Гарасат» (икенче исеме «Чулпан таңны уята», 1973 тә шул ук театрда куела) пьесалары авторы. С.ның әсәрләренә катлаулы сюжет, үзенчәлекле характерлар хас, автор геройларның күңел дөньясын нечкә психол. алымнар б-н ачып бирергә сәләтле. С.ның әсәрләре, бигрәк тә хикәяләре, сәнгатьчә эшләнеше, идея-эстетик кыйммәте ягыннан югары сыйфатлы булулары б-н аерылып тора. С. әдәби тәрҗемәләре б-н дә укучыларга таныш. Ул П.Л.Трэверсның «Мэри Поппинс» (1972), Р.Э.Распеның «Барон фон Мюнхгаузен маҗаралары» («Приключения барона Мюнхгаузена», 1974), Ф.Зальтенның «Урман әкияте» («Бемби», 1980) повестьларын татар теленә тәрҗемә итә.

*Әд.:* Х у җ и н М. Өч күңел // Казан утлары. 1999. № 8; Ш а б а е в М. Ихлас күңелле авылдашым // Казан утлары. 2002. № 6. *Г.М.Габделхакова.*

**САБИ́ТОВ** Гайнетдин (1858–1917 елдан соң), Казан сәүдәгәре. Түбәтәй, кәләпүш, калфак һ.б. баш киемнәре тегеп сатучы ширкәт хуҗасы. Җитештерелгән әйберләр Амстердамда (1883, Зур көмеш медаль), Лондонда (1884, Зур алтын медаль; 1885, Зур бронза медаль), Парижда (1888, Зур көмеш медаль), Неапольдә (1913, Гран-при һәм Зур алтын медаль) узган халыкара күргәзмәләрдә бүләкләнә. 1912 елда уллары Нәҗметдин һәм Сәлахетдин б-н берлектә, җитештерелгән әйберләрне сату максаты б-н, 50 мең устав капиталы булган «Г.Сабитов һәм уллары» сәүдә йорты оештыра. Идел-Урал төбәгенең барлык зур ярминкәләрендә аның бүлекчәләре була. 20 йөз башында Борнай һәм Юнисовлар (Казан) мәчетләренең җәмәгать идарәчесе.

*Әд.:* Подробный прейскурант Торгового Дома «Г.Сабитов с сыновьями». К., 1914. *Р.Р.Салихов.*

**САБИ́ТОВ** Иҗат Хак улы (15.12.1937, Мәскәү өлкәсе Воскресенск ш.), математик, физика-матем. фән. д-ры (1997), проф. (2005). С.М.*Сабитовның* онытгы. 1959 елда Таҗик ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1961 дән Мәскәү ун-тында, матем. анализ каф. профессоры (2001 дән). Хезмәтләре өслекләр һәм күпкырлыкларның метрик геометриясенә карый. С. кабарынкы өслек регулярлыгы б-н аның метрик регулярлыгының тәңгәллеге турындагы теореманы исбатлый, күпкырлык күләме өчен Герон формуласы аналогын чыгара, бөгелүчән күпкырлык күләменең даимилеген күрсәтә, күпкырлыклар метрик теориясенең төп проблемаларына алгоритмик чишелеш таба.

Х е з м.: Күпкырлыкларның күләмнәре. К., 2006; Локальная теория изгибаний поверхностей // Итоги науки и техники. Современные проблемы математики. Фундаментальные направления / ВИНИТИ. 1989. Т. 48; Isometric Immersions and Embeddings of

Locally Euclidean Metrics // Cambridge Scientific Publishers. Series Reviews in Mathematics and Mathematical Physics. 2009. V.13, part 1.

**САБИ́ТОВ** Наил Харис улы (21.5.1953, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2001), проф. (2008). Казан мәдәният ин-тын (1976), Казан финанс-икътисад ин-тын (1983) тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген 1969 елда Казан моторлар төзү з-дында башлый. 1972–76 елларда «Теплоконтроль» з-ды клубы җитәкчесе, 1976–83 тә Казан финанс-икътисад ин-тының студентлар клубы директоры. 1983–92 дә Казан химия-технол. ин-тында икътисад каф. укытучысы. 1992–2001 дә Казан мед. академиясенең сәламәтлек саклау икътисады каф. доценты, 2001 дән РФ Үзәк банкының Казан банк мәктәбе укытучысы. Төп хезмәтләре икътисадны акча-кредит яссылыгында көйләү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Организация и экономика сферы медицинских услуг. К., 2000; Теория и практика денежно-кредитного регулирования. К., 2006; Денежно-кредитная сфера в экономике России. К., 2008.

**САБИ́ТОВ** Нариман Гыйләҗетдин улы (11.1.1925, Казан — 9.6.1971, Севастополь; Уфада җирләнә), композитор, дирижёр, БАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1961). Мәскәү консерваториясе каршындагы Башкорт опера студиясен композиция (В.Белый классы) һәм дирижёрлык (И.Дружинин классы) буенча (1948), Мәскәү консерваториясен композиция (А.Александров классы) һәм симф. дирижёрлык (И.Дружинин классы) буенча (1953) тәмамлый. 1953–71 елларда Башкорт опера һәм балет театры дирижёры (1954–60 та, 1969 дан баш дирижёр). Актив концерт һәм муз.-агарту эшчәнлеге алып бара, башкорт композиторлары әсәрләре җыентыкларын төзи һәм редакцияли. Башкорт балеты һәм симф.-камера-вокаль музыка үсешенә булышлык итә. Башкортстанның хәзерге муз. культурасы формалашуына һәм үсешенә зур өлеш кертә. С.ның композиторлык иҗаты жанр төрлелеге һәм музыка теленең үзенчәлеге б-н аерылып тора. 1954–71 дә Башкорт опера һәм балет театрында куелган опера һәм алты балет; башкорт шагыйрьләре шигырьләренә хор һәм симф. оркестр өчен өч кантата, оркестр б-н скрипка өчен өч концерт, оркестр б-н фортепиано өчен концерт, өч прелюдия; вокаль цикллар, романс һәм җырлар; драма спектакльләренә музыка һ.б. әсәрләр авторы. БАССРның С.Юлаев исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1972).

*Әд.:* Б и к ч е н т а е в А. Нариман Сабитов. Уфа, 1968. *Ф.Ш.Салитова.*

**САБИ́ТОВ** Рәшит Мәхмүт улы (27.3.1937, БАССРның Гафури р-ны Ялгыз Каен а.), язучы, БРның атказ. мәдәният эшлеклесе (1997). Башкорт ун-тын тәмамлагач (1967), Кырмыскалы р-ны мәктәпләрендә укыта. 1968 елдан Уфада яши. «Кызыл таң» г-тасында әдәби хезмәткәр булып эшли, 1975 тән «Пионер» ж-лы редакциясендә бүлек мөдире, бер үк вакытта, 1975–88 елларда, Башкортстан китап нәшриятының балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты бүлегендә өлкән мөхәррир. 1991–93 тә «Кызыл таң» г-тасында күзәтүче, 1993–97 дә «Zaman-Bashkortostan» г-тасы хәбәрчесе. 2004 тән БР Язучылар берлегенең татар язучылары секциясен җитәкли, 2011 елга кадәр әдәби консультант. «Йәшлегем йөҙө» (Уфа, 1980), «Һаумы, мәктәп!» (Уфа, 1983) җыентыкларына кергән беренче шигырьләре, нигездә, комсомолга, эшче яшьләр темасына багышлана. «Ылаҫындар бейек оса» (Уфа, 1981), «Ҡыйғаҡ-ҡыйғаҡ ҡаҙ ҡыҫҡыра» (Уфа, 1985), «Һүнгән йондоҙ яҡтыһы» (Уфа, 1988), «Батырлар кайда туа?» (Уфа, 1996), «Ташламачы, мәхәббәтем» (Уфа, 2005), «Мәхәббәт өянәге» (Уфа, 2006) җыентыкларындагы хикәя һәм повестьларында яшь геройларның яшәү рәвеше, шөгыльләре мавыктыргыч вакыйгалар аша сурәтләнә.

**САБИ́ТОВ** Рөстәм Нариман улы (5.12.1955, Уфа), композитор, дирижёр, БРның һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1997, 2000). 1980 елда Уфа сәнгать ин-тын композиция буенча (Е.Земцов классы) тәмамлый. 1983 тән Башкорт опера һәм балет театры дирижёры. 1992 дән Башкортстан Респ-касы Композиторлар берлеге идарәсе рәисе, 2012 дән Башкорт дәүләт опера һәм балет театрын җитәкли. С., башлыча, игътибарын симф. һәм камера музыкасына бирә.

Төп әсәрләре: Оркестр б-н скрипка өчен концерт (1980); Соло гобой б-н кыллы оркестр өчен концерт (1984); Симф. күренешләр (1992); К.Хитомара һәм О.Якимото шигырьләренә «Япон поэзиясеннән» хор циклы (1978); С.Маршак шигырьләре һәм рус халык текстларына балалар хоры өчен «Балалар» миниатюралары (1985); кыллы оркестр һәм бәрмә уен кораллары өчен «Әткәй истәлегенә» поэмасы (1987); кыллы ике квартет (1978, 1992): «Г.Лорка шигырьләренә биш романс» вокаль циклы (1976) һ.б. БРның С.Юлаев исем. Дәүләт бүләге (2010), Д.Д.Шостакович исем. Россия композиторлар берлеге бүләге (2012) лауреаты .

**САБИ́ТОВ** Салих Гыйззәт улы (10.10.1912, БАССРның Шаран р-ны Ерёмкино а. — 18.5.1979, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (1.9.1944, 2.4.1945, 27.6.1945), гв. кече сержанты. Туган авылында колхозда бригадир булып эшли. 1941 елның июненнән Кызыл Армия сафларында. 1941 нең декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 175 нче гв. укчы полкында 82 *мм* лы миномёт төзәүчесе (5 нче гв. армиясенең 58 нче гв. укчы полкы). Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск (1943) сугышында, Кировоград (1944), Сандомир-Силезия (1945) һәм Берлин (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 9–11 августында Ратай тимер юл станциясе (Сташув шәһәреннән 26 *км* көньяк-көнбатыштарак, Польша) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: дошманның 3 ут ноктасын, дистәдән артык солдатын юк итә, шуның б-н ул укчы подразделениеләргә алга үтәргә булыша; 1945 нең 20 гыйнварында полк Одер елгасының сулъяк ярындагы Оттозее торак пункты р-нында (Ополе шәһәреннән 8 *км* төньяк-көнбатыштарак, Польша) плацдарм яулаганда дошманның 4 ут ноктасын юк итә; 1945 нең 16 апрелендә Нейсе елгасын кичкәндә (Мискац шәһәреннән төньяктарак, Германия) яралы расчёт командирын алыштырып, миномёт уты б-н җитәкчелек итә, һөҗүм итүче подразделениеләрне ышыклап, аларга елга аша кичүне җиңеләйтә. С. җитәкчелегендәге миномётчылар, укчы батальонга елга кичкәндә булышлык күрсәтеп, тулы бер отделение пехотаны һәм 2 пулемёт ноктасын юк итәләр. 1945 тә демобилизацияләнгәннән соң, туган авылында яши, колхозда эшли. 2 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.



С.Г.Сабитов.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**САБИ́ТОВ** Сәрвәретдин Мифтахетдин улы (1862, Казан губ. Чистай өязе, башка мәгълүматлар буенча, Самара губ. Бөгелмә өязе — 1920 яки 1922), дин эшлеклесе. Оренбург губернасындагы Троицк мәдрәсәсендә укыганнан соң, 1890–1913 елларда шул ук төбәктәге Бушман-Суун-Кара-Кыпчак волостеның Тләүмбәт авылы имам-хатыйбы һәм мәдрәсәдә мөдәррис булып эшли, 1913 тән — Оренбург губернасының Оренбург өязендәге Югары Биккүз авылында. Бер үк вакытта үзе оештырган «Бушман-Суун-Кара-Кыпчак волосте мөселманнары җәмгыяте» идарәсе рәисе. Оренбург губернасында яңа ысуллы мөселман мәктәпләре ачуга зур игътибар бирә. Хезмәтләре исламият, педагогика һәм татарларга рухи-әхлакый тәрбия бирүгә карый.

Х е з м.: Вазаифе инсан. К., 1898; Адабе тәзәүүеҗ. Оренбург, 1908; Ислам, тәрәккый, ислах. К., 1913.

*Әд.:* С а б и т о в И.Х. Мечтаю вернуть имя деду // Татарские новости. 2008. № 3.

**САБИ́ТОВА** Надия Михайловна (3.11.1953, Куйбышев ш.), икътисад фән. д-ры (2003), проф. (2006). Казан финанс-икътисад ин-тын (хәзер Казан ун-тының Идарә, икътисад һәм финанс ин-ты) тәмамлый (1975), шунда ук эшли, финанс каф. мөдире (1990–2000 дә һәм 2003 тән). Фәнни тикшеренүләре РФдә бюджет төзелеше, бюджет өлкәсендә хокук мөнәсәбәтләрен камилләштерү мәсьәләләрен өйрәнүгә карый. Проф. А.М.*Ляндо* җитәкчелегендә пр-тиенең финанс-кредит планын эшләүдә катнаша (1975–78), РФ бюджет системасының нәтиҗәлелегенә бәя бирә (2000–03).

Х е з м.: Бюджетное устройство Российской Федерации: теоретические аспекты. К., 2001; Бюджет и бюджетная политика субъекта Российской Федерации: Учеб. М., 2003 (автордаш); К вопросу о реформировании бюджетного процесса в РФ // Финансы и кредит. 2006. № 6.

**САБЛУ́КОВ** Гордий Семёнович (1804, Оренбург губ., Эстәрлетамак өязе Архангельский заводы, башка мәгълүматлар буенча Аскын заводы — 29.1.1880, Казан), төрки, гарәп телләре белгече, ислам дине белгече, миссионер. Оренбург руханилар семинариясен (1826), Мәскәү руханилар академиясен (1830) тәмамлый. Үзлегеннән фарсы һәм га-

рәп телләрен өйрәнә. 1830–49 елларда Саратов руханилар семинариясендә (укучылар арасында — Н.Г.Чернышевский һәм публицист Г.Е.Благосветлов) тарих, яһүд, грек һәм татар телләрен укыта. 1849–62 дә Казан руханилар академиясендә татар һәм гарәп телләрен укыта. 1849 дан православие гыйбадәтләрен татар теленә тәрҗемә итү комиссиясе әгъзасы. Гомеренең Саратов чорында Идел буе халыкларының этнографиясен өйрәнә. Алтын Урданың Сарай әл-Мәхрусә, Сарай әл-Җәдид һәм Үкәк шәһәрләрендә тарихи-археол. һәм нумизматик тикшеренүләр үткәрә, анда табылган Алтын Урда акчалары тупланмасының исемлеген төзи. 1848 дә *Ибне Фазланның* руслар турындагы хикәятенең Х.Д.Френ бастырган текст нигезендә тәрҗемәсен басмага әзерли. Татар һәм төрки телләр белеме буенча «Татар грамматикасы» («Татарская грамматика»), «Рус телендә татар-монгол сүзләрен тарихи-филологик аңлату» («Историко-филологическое объяснение татарско-монгольских слов в русском языке»), «А.Троянскийның 2000 тирәсе китап һәм халык теле сүзләре өстәлгән татарча сүзлеге» («Татарский словарь А.Троянского с дополнениями до 2000 слов книжного и народного языка»), «Татар теленең синоним сүзләр җыентыгы» («Свод синонимических слов татарского языка») хезмәтләре (Казанда 1856 ның 5 июнь янгыны вакытында югалалар) авторы. Саратовта һәм Казанда Хива ханы һәм тарихчы *Әбелгазый Баһадур ханның* «Төркиләрнең нәсел шәҗәрәсе» әсәренең төп язмасын өйрәнеп тәрҗемә итә. Гомеренең Казан чорында исламны өйрәнү б-н шөгыльләнә. «Коръән»не (1877) һәм «Коръән тәрҗемәсенә кушымталар»ны (1879) рус теленә тәрҗемә итә, *хәдисләрне* өйрәнә. Хезмәтләре Идел буе һәм Алтын Урда тарихына, нумизматика, археология, этнографиягә карый.

Х е з м.: Исследование о месте Сарая, столицы Кипчакской Орды // Уч. зап. Казан. ун-та. 1842. Т. 2; История Абуль-Гази // Библиотека восточных историков, издаваемая И.Березиным, проф. Казан. ун-та. К., 1854. Т. 3, ч. 1; Путевые записки двух Хаджиев: 1751 и 1783 года. К., 1862; Сведения о Коране, законоположительной книге мохаммеданского вероучения. К., 1884; Очерки внутреннего состояния Кипчакского царства // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1896. Т. 13, вып. 3.

*Әд.:* К р а ч к о в с к и й И.Ю. Чернышевский и ориенталист Г.С.Саблуков // Избр. соч. М.–Л., 1955. Т. 1; Библиогр. словарь отечественных тюркологов: Дооктябрьский период. М., 1989; В а л е е в Р.М. Из истории Казанского востоковедения середины — второй половины XIX в.: Гордий Семёнович Саблуков — тюрколог и исламовед. К., 1993.

*Р.М.Вәлиев.*

**САБУ́РОВ** Богдан (Феофан) Юрьевич (? — 1598, Мәскәү), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, бояр (1572). 1558–59 елларда Ливон сугышында катнаша («башлык», воевода). 1564 тә Себеж шәһәрендә 1 нче (баш) воевода. Кызы Евдокиянең патша Иван IV нең улы Иванга кияүгә чыгуы С.ның карьерасына уңай йогынты ясый. 2 елдан Евдокиянең монастырьга җибәрелүенә карамастан, С. түрә дәрәҗәсен саклап кала. *Казан ханлыгы яуланганнан соңгы фетнә-чуалышлар* вакытында, 1573 тә, татарларга һәм мариларга каршы яуда алдынгы полкның 1 нче (баш) воеводасы. 1575–76 да Чабаксарда, 1577–81 дә Казанда воевода; 1579–80 дә, А.И.*Ногтев* вафатыннан соң, 1 нче (баш) воевода вазифаларын башкара. С. идарә иткән дәвердә *Казан Мәрьям Ана иконасы* табыла һәм шөһрәт ителә. 1581–84 тә Зөя шәһәрендә 1 нче (баш) воевода. 1587 дә Смоленск шәһәрендә воевода.

*Е.В.Липаков.*

**САБУ́РОВА** Ригина Васильевна (21.11.1939, Казан — 12.7.2013, шунда ук), физик, физика-матем. фән. д-ры (1990). 1962 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1993 тән). 1999 дан Казан энергетика ун-тының физика каф. профессоры. Хезмәтләре каты аморф җисемнәр теориясенә карый. С. катышмалы кристаллар һәм пыялаларны тикшерүнең яңа алымнарын (акустик параэлектрик резонанс, параэлектрик туннель кайтавазы), аларны релаксацияләү механизмнарын тәкъдим итә. Спинлы квант пыялалардагы фаза күчешләре теориясендә аркылы кырның ролен ачыклый. Диполь пыялаларда һәм тәртипкә салынмаган башка каты җисемнәрдә кайтавазның яңа сигналларын таба.

Х е з м.: Параэлектрический резонанс. М., 1982 (автордаш); Нелинейная восприимчивость изинговского спинового стекла в поперечном поле // Письма в Журн. эксперим. и теорет. физики. 1991. Т. 54, № 5 (автордаш); Неравновесная динамика квантового спинового стекла в переменном магнитном поле // Физика твёрдого тела. 2004. Т. 46, вып. 2 (автордаш).

**САБУ́РСКАЯ** Сәрия Харис кызы (27.9.1956, Яшел Үзән ш., ТАССР), хакимият эшлеклесе, ТРның атказ. мәктәп укытучысы (1996), ТРның атказ. халыкны социаль яклау хезмәткәре (2006). Казан пед. ин-тын (1980), «ТИСБИ» идарә ун-тын (2013) тәмамлый. 1980–82 елларда 14 нче Яшел Үзән урта мәктәбендә укыта. 1982–83 тә ВЛКСМның Яшел Үзән шәһәр ком-ты секретаре. 1983–88 дә КПССның Яшел Үзән шәһәр ком-тында инструктор. 1988–2001 дә Яшел Үзән р-ны һәм Яшел Үзән шәһәре хакимиятендә: халык мәгарифе бүлеге мөдире (1993 кә кадәр), 1993 тән хакимият башлыгы урынбасары һәм бер үк вакытта, 2000 нән, аппарат җитәкчесе. 2001–10 да ТР МК Аппаратында бүлек башлыгы. 2010 нан ТРда кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил. Медальләр б-н бүләкләнә.

**«САБЫЙГА́»**, балалар өчен әдәби-нәфис журнал. Оештыручылары — «Мирас» ж-лы редакциясенең хезмәт коллективы, ТР Мәгариф министрлыгы. 1994 елдан Казанда татар һәм рус телләрендә нәшер ителә. Башлап җибәрүчесе һәм баш мөхәррире — М.Ж.*Сәхапов*. Журнал эчтәлегенең күп өлешен тарихи-мәдәни мирас ядкәрләре, балалар прозасы, поэзия, публицистика, драматургиясе, фольклоры алып тора. Төп темалар — татар халкының тарихи-мәдәни мирасын тергезү, татар телен өйрәнү, әхлакый тәрбия, мәктәпкәчә яшьтәге, өлкән һәм кече яшьтәге мәктәп балаларының акыл үсеше мәсьәләләре һәм аларның иҗатын пропагандалау. 2010 да журнал чыгудан туктый.

**САБЫЙЛА́Р ҮЛЕМЕ́**, к. *Балалар үлеме*.

**САБЫ́Н ҖИТЕШТЕРҮ́**, химия сәнәгате тармагы. Казанда 16 йөзнең 2 нче яртысыннан мәгълүм. Башта кәсеп б-н берничә рус «сабынчы»-һөнәрчесе шөгыльләнә (1646 елда — 4 кеше). Яллы хезмәт файдаланылган сабын кайнату пр-тиеләре сәүдәгәрләр тарафыннан 18 йөздә, бигрәк тә аның 2 нче яртысыннан актив рәвештә ачыла башлый. 1799 да алар өчен Иске Татар бистәсе б-н Яңа Татар бистәсе арасында махсус урын бүлеп бирелә (соңрак ул Сабынчы урамы дип атала). 1812 дә 3–7 кайнату казаны булган 23 сабын кайнату пр-тиесендә (иң эреләренең хуҗалары — Адамовлар, *Апанаевлар*, П.Евреинов, *Замановлар*, Китаевлар, А.И.*Квасников*, А.И. һәм П.И.Котеловлар, Хәлфиннәр, Я. һәм Ю.Шатуновлар, *Юнысовлар*) 40 оста һәм 183 эшче эшли. Сабын ясау махсус белем һәм күнекмәләр булуны таләп иткән, шуңа күрә, губерна сәнәгатенең башка тармакларына караганда, С.ж.дә хезмәт хакы югарырак булган (эшчеләрнеке елга 80–150, осталарныкы 200–400 сум). Елга 1,2 млн. сумлык төрле сортлы (хуш исле, майлы, йомырка сабыны һ.б.) 100–160 мең пот сабын җитештерелә. Кайбер пр-тиеләр ш.у. терлек маеннан шәмнәр эшләп чыгаралар. Сабынны үсемлек көле, известь һәм аш тозы кушып мөгезле вак терлек маеннан кайнатканнар. Соңрак поташ (углекислый калий) кулланыла башлый. Терлек мае Оренбург һәм Уфа губерналарыннан, Казакъстаннан кертелә. Чимал ш.у. терлек мае эретү һәм *селте-поташ кәсепчелеге* б-н шөгыльләнгән заводлардан һәм артельләрдән дә китерелә. Продукция С.-Петербургта, Мәскәүдә, Мәкәрҗә (Түбән Новгород), Ростов, Ирбет ярминкәләрендә сатыла. Казан сабыны илдә иң яхшы сабын булып саналган. Россия эшләнмәләренең 2 нче Ачык күргәзмәсендә (Мәскәү, 1839) Ә.И.Заманов б-н Г.М.Юнысов хуш исле һәм гади сабын өчен көмеш медаль алалар һәм рәсми мактауга лаек булалар. Майлар химиясе үсеше һәм стеарин алыну (француз химигы М.Э.Шеврёль хезмәтләре, 1813–23), ш.у. соданы күпләп җитештерү ысулы уйлап табылу (француз химигы Н.Леблан, 1820) эре сәнәгый күләмдә С.ж. булдыруга мөмкинлек тудыра. Казанның вак сабын кайнату пр-тиеләре Россиянең үзәк өлкәләрендә төзелгән фабрикалар һәм заводлар б-н көндәшлек итүгә сәләтле булмыйлар. Бәя төшерергә омтылып, алар продукциянең сыйфатын түбәнәйтәләр, тора-бара таркалу хәленә килеп ябылалар: 1854 тә 15 пр-тие исәпләнә, 1888 дә шуларның 6 сы гына (24 эшче) кала. Җирле С.ж. 1855 тә яңа этәргеч ала, шул елда А.К., В.К. һәм И.К.*Крестовниковлар* тарафыннан *Шәм-стеарин, сабын кайнату, глицерин җитештерү химия заводына* нигез салына, анда химиядәге алдынгы казанышлар һәм җитештерүне оештыру ысуллары файдаланыла. 1861 дә төрле сортлы сабын җитештерү 2 мең *т*, даими эшләүчеләр саны 355 кеше тәшкил итә. Шул ук елда завод продукциясе Мәскәүдә һәм Лондонда узган күргәзмәләрдә бүләкләргә лаек була. 1860–70 еллардагы реконструкция ба-

рышында завод киңәйтелә һәм механикалаштырыла (терлек маеннан стеарин һәм сабын, стеариннан шәм ясауның барлык стадияләре кушыла), ул ш.у. үз ихтыяҗлары өчен өстәмә продуктлар (күкерт к-тасы, известь һ.б.), савытлар (әрҗәләр, мичкәләр) эшләп чыгара. 1888 дә эшчеләр саны — 900, 1894 тә — 1050, 1914 тә 2200 кешегә җитә. 1894 тә 3 млн. 783 мең сумлык 648 мең пот сабын, шәмнәр, алеин һәм глицерин җитештерелә. Завод хисабына илдә җитештерелгән сабын һәм шәмнәрнең 10% тан артык өлеше туры килә. Барлык вак пр-тиеләр национализацияләнгәннән (1919–20) һәм ябылганнан соң, С.ж. тулысынча М.Вахитов исем. 1 нче сабын кайнату, шәм һәм химия з-дында җәелдерелә (к. «*Нэфис Косметикс*»).

Хәзерге сабын кайнату пр-тиеләре төрле типтагы һәм сорттагы кер сабыны, исле һәм техник сабыннар; каты, йомшак, сыек, порошок хәлендәге сабыннар эшләп чыгара. Майлы чимал буларак терлек һәм үсемлек майлары, ш.у. майны алмаштыргыч матдәләр — синтетик майлы к-талар, канифоль, нафтен к-талары, талл мае кулланыла. Синтетик юу чаралары күбәю һәм чимал буларак терлек маена кытлык арту шартларында кер сабынын җитештерү кими бара. Көнкүрештә шәхси гигиена чарасы буларак һәм сәнәгатьнең төрле тармакларында (бигрәк тә текстиль сәнәгатендә) сабын киң кулланыла. Ул чылаткыч матдә, эмульгатор, коллоид-дисперс системаларны тотрыклыландыручы буларак; металл эшкәртү станокларын майлау-суыту сыеклыклары составында; файдалы казылмаларны флотация б-н баетканда; полимерларны эмульсия ысулы б-н синтезлаганда, лак-буяу продукциясе җитештергәндә файдаланыла; куерткыч матдә сыйфатында пластик майлар һәм кибүне тизләтү чарасы буларак майлы лаклар, олифа һ.б. составына керә. 2013 тә ТРда 8,3 мең *т* исле сабын, 0,4 мең *т* кер сабыны җитештерелә.

*Әд.:* Ключевич А.С. Из истории материальной культуры и народного хозяйства России: Моющие средства, переработка жиров с древнейших времён до 1917 г. К., 1971.

*С.Г.Белов.*

**САБЫ́Н ҮЛӘНЕ́**, сапонария (Saponaria), каннәферчәләр семьялыгыннан бер- яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 30 дан артык төре билгеле, Евразиянең уртача поясында таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — дарулы С.ү. (S. officinalis) барлык районнарда очрый. Болыннарда, елга үзәннәрендә, урман буйларында үсә. 30–90 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамырчасы нәзек, шуышма, кызгылт-коңгырт төстә. Сабагы туры, цилиндрсыман, югары өлешендә тармаклы. Яфраклары озынча, очлы, кыска сапларда, буй җепселле. Чәчәкләре зур, алсу яки ак төстә, хуш исле, калкан-себеркәч чәчәк төркемендә. Җимеше — күп санлы бөерсыман вак кара орлыклардан торучы бер оялы тартмачык. Июнь–августта чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Тамырча һәм тамырларында сапониннар, лайла, пектиннар бар; яфракларында — С витамины. Халык медицинасында тамыр төнәтмәсе какырык куптару, эч йомшарту һәм бәвел кудыру чарасы буларак, ш.у. тире авырулары вакытында кулланыла. С.ү.нең катмарлы формалары декоратив үсемлек буларак үстерелә. Үләне терлек өчен агулы.

**САВАРЕ́НСКИЙ** Фёдор Петрович (11.2.1881, хәзер Владимир өлкәсе Гороховец а. — 8.10.1946, Мәскәү), гидрогеолог, СССР ФА академигы (1943; 1939 елдан мөхбир әгъза). Инженерлык геологиясенә нигез салучыларның берсе. Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1909), Геол. ком-тының Мәскәү бүлегендә эшли. 1922 елдан СССР Игенчелек халык комис-тында, 1924 тән Геол. ком-тында, 1929 дан Җир асты сулары ин-тында, проф. (1930 дан), 1933 тән Бөтенсоюз минераль чимал ин-тында, 1935 тән СССР ФАнең Геол. ин-тында. 1942–44 тә Казанда, оборона ихтыяҗы өчен Урта Идел һәм Кама буе ресурсларын мобилизацияләү буенча СССР ФА комиссиясенең су хуҗалыгы секциясе рәисе. 1944 тән СССР ФАнең Гидрогеология проблемалары лаб-ясе директоры. Хезмәтләре гидрогеологиягә, инженерлык геологиясенә, туфрак белеменә карый. С. Идел буе төбәгендә гидрогеологик төшерүләр үткәрә (1915–22), аның җитәкчелегендә СССР, ш.у. Татарстанның җир асты сулары буенча беренче белешмәлек төзелә (1933). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Избр. соч. М.–Л., 1950.

**САВГА́Ч** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 18 *км* төньяктарак, Саурыш елгасы буенда. 2010 елда 672 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Гимназия, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз уртасына кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новопоселённая Савгачева исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 695 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәм волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 75 ир-ат; 1859 да — 439, 1897 дә — 302, 1908 дә — 421, 1920 дә — 479, 1926 да — 400, 1938 дә — 502, 1949 да — 427, 1958 дә — 431, 1970 тә — 449, 1979 да — 718, 1989 да — 754, 2002 дә — 672 кеше.

**САВЕ́ЛЬЕВ** Александр Степанович (9.6.1820, С.-Петербург — 6.5.1860, шунда ук), физик, физика һәм химия д-ры (1852). Акад. Э.Х.Ленц шәкерте. Петербург ун-тын матем. фән. канд. дәрәҗәсендә тәмамлый (1840). Петербург ФАнең Ак диңгезгә һәм Төньяк Боз океанына экспедициясендә магнетик һәм географик үлчәүләр алу максатында катнаша (1841). 1846 елда Казан ун-тының физика һәм физик география кафедрасы буенча адъюнкт итеп билгеләнә, проф. (1854 тән). 1855 тән Константин исем. межалау ин-тында (Мәскәү). 1857 дән С.-Петербургның хәрби уку йортларында укыта. Хезмәтләре суларның, эремәләрнең электр үткәрүчәнлегенә, электрохимиягә карый. 1853 нең 30 мартында, рус инженеры П.Н.Яблочковның 1876 да электр шәме ачуыннан күпкә алданрак, С. Казан ун-ты ишегалдын гальваник яктырту буенча тәҗрибә үткәрә. С.ның «Сыеклыкларның гальваник үткәрүчәнлеге турында» дип аталган докторлык диссертациясе 1853 тә Петербург ФАнең Демидов бүләгенә лаек була.

Хезм.: О явлении поляризации в гальванической цепи. СПб., 1845; Физический кабинет Казанского университета // Журн. М-ва нар. просвещения. 1849. № 64.

*Р.Г. Усманов.*

**САВЕ́ЛЬЕВ** Анатолий Александрович (15.3.1957, Яшел Үзән ш.), эколог, биол. фән. д-ры (2005), проф. (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1979), шунда ук эшли. Хезмәтләре экологиядә фәзалы модельләштерүгә карый. Үсемлек бергәлекләренең ихтималлык моделен төзи. Аның тарафыннан эшләнгән концепцияләр, матем. модельләр һәм компьютер программалары «Татнефть» АҖ объектларының әйләнә-тирә мохиткә ясаган тәэсирен күләм буенча исәпләү» проекты кысаларында терр-яләрне районлаштыру һәм экологик комплекслы бәяләүдә, 1994–2000 елларга РФнең минераль чимал базасын үстерү буенча Федераль максатчан программаны гамәлгә ашыруда һ.б.да кулланыла. Җирне дистанцион зондлаштыру, экология белеме, интеллектуаль һәм адаптив системалар һ.б.га караган мәкаләләр авторы. ТРның Фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге лауреаты (2004).

Хезм.: Моделирование пространственной структуры растительного покрова (Геоинформационный подход). К., 2004; Вероятностная модель формирования флористического состава растительных сообществ // Ботанический журн. 2005. Т. 90, № 3 (автордаш); Spatially continuous data analysis and modelling. Analysing Ecological Data (Statistics for Biology and Health). N.Y., 2007.

**САВЕ́ЛЬЕВ** Виктор Константинович (1.4.1810, Түбән Новгород губ. Горбатов ш. — 23.3.1882, Казан), нумизмат, коллекционер. 1824–31 елларда Түбән Новгород казна палатасында, 1831–45 тә Казан, 1845–48 дә Петербург участок округлары попечительләр канцеляриясендә эшли. 1848–64 тә отставкада, Түбән Новгород тракты буенча ирекле почталар конторасы управляющие була. 1864 тән Казан ун-тында, 1866 дан идарә секретаре һәм казначей. Петербург археол. җәмгыяте әгъзасы, Мәскәү археол. җәмгыяте мөхбир әгъзасы, Казан ун-ты каршындагы Археол., тарих һәм этнография җәмгыятен оештыручы, әгъзасы (1878). 1869 да 1 нче археол. съезды эшендә катнаша (Мәскәү), Болгар шәһәре хәрабәләрендә табылган Алтын Урда акчалары хәзинәләре турында доклад б-н чыга. Казанда уздырылган *Дүртенче археология съездын* оештыручыларның берсе (1877, съездның Башлангыч ком-ты әгъзасы һәм казначысы), анда «Акчаларга нисбәттә Маҗар һәм Болгар шәһәрләре турында» темасы буенча чыгыш ясый.

С.ның акчалар һәм борынгы әйберләр коллекцияләре Казаннан һәм Россиядән читтә дә мәгълүм була. Әмма ул, акчага бик тә мохтаҗлыгы аркасында, аларның кайберләрен яңа-



П.Ф. Савельев.



Ф.П. Савельев.

ларын алу өчен сатып җибәрергә мәҗбүр була. 1861 дә С. болгарларга нисбәтле борынгы әйберләр һәм акчалар коллекциясен тәхет варисы Николай Александровичка тапшыра, аңардан рәхмәт йөзеннән кыйммәтле йөзек кабул итә. Авыл кешеләре тарафыннан 1856 да табылган Тәтеш хәзинәсен (10 меңгә якын тәңкә) саклап калуга зур өлеш кертә. Хәзинә, башлыча, Туктамыш, аның элгәрләре һәм чыңгызыйларның башка династияләре акчаларыннан тора. Танылган Петербург шәркыятьчесе П.С.Савельев хәзинәнең исемлеген бастырып чыгара һәм анда моңа кадәр билгеле булмаган күп кенә акчалар, элек беренди дә мәгълүмат табылмаган дүрт ханның исеме ачыклануын күрсәтә. П.С.Савельев С.ны «тырыш Казан нумизматы» дип атый. С.ның вафатыннан соң аның коллекциясенең бер өлеше варисларыннан А.Ф.Лихачёв тарафыннан 1883 тә һәм 1889 да сатып алына. Казан ун-тының Нумизматика музее С.ның хатыныннан борынгы грек, Рим консуллары һәм императорлары, Парфия, Иран, Җүчиләр акчаларын сатып ала. Хезмәтләре Шәрекъ (Җүчиләр) һәм рус нумизматикасын өйрәнүгә карый.

Хезм.: Описание русских монет, найденных в 1854 г. близ Казани. СПб., 1856; О кладах золотоордынских монет в развалинах древнего города Болгар // Тр. 1 археол. съезда в Москве в 1869 г. М., 1871. Т. 2; Описание двух коллекций джучидских медных монет, принесённых в дар Обществу археологии, истории и этнографии В.М.Эленд и К.Я.Михайловым // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. К., 1884. Т. 3.

*Әд.:* Загоскин Н.П. Описание клада золотоордынских и некоторых других монет, найденного в 1881 г. близ села Малого Толкиша Чистопольского уезда Казанской губернии. К., 1882; Русский биографический словарь. СПб., 1904. Т. 18.

*А.З.Сингатуллина.*

**САВЕ́ЛЬЕВ** Николай Алексеевич (16.5.1931, Чистай р-ны Керәшен Ялтаны а.), галим агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССР, РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1947, 1992). Чистай совхоз-техникумын (1949), Казан а.х. ин-тын (1963) тәмамлый. 1949–2000 елларда Чистай р-нында: Татар Ялтаны МТСында учётчик, агроном (1951 дән), Ленин исем. к-зда баш агроном (1956 дан), «Алга» с-зы бүлеге управляющие (1958 дән), «Искра» с-зында баш агроном (1965 тән), партком секретаре (1968 дән), «Йолдыз» с-зы директоры (1971 дән). С. җитәкчелегендә «Йолдыз» с-зында 5 мең баш мөгезле эре терлек, 3 мең баш дуңгыз симертүгә исәпләнгән фермалар, 5 мең $м^2$ дан артык торак, урта мәктәп, мәдәният сарае һ.б. житештерү, социаль-мәдәният һәм көнкүреш биналары төзелә. Ит сатуның еллык күләме 3 мең *т* га җитә, бер баш мөгезле эре терлекнең уртача тәүлеклек артымы — 800 *г*, дуңгызныкы — 640 *г* була. 1991–92 дә ТССР ЮС, 1992–95 тә ТР ЮС депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**САВЕ́ЛЬЕВ** Павел Степанович (23.6.1814, С.-Петербург — 19.5.1859, шунда ук), шәркыятьче галим, нумизмат, археолог, публицист. 1830–35 елларда Петербург ун-тының филол. ф-тында, Көнчыгыш телләр ин-тында укый; Х.М.*Френ* һәм шәркыятьче галим О.И.Сенковский шәкерте. 1837–41 дә Петербург ФА идарәсе ком-ты каршында чиновник. 1841–52 дә Чит ил цензурасы ком-ты секретаре. С.-Петербургта Рус археол. җәмгыятен оештыручы һәм җитәкчеләреннән берсе (1847), 1849 дан рус телендә хат алышу буенча секретарь, 1850 дән җәмгыятьнең «Записки» басмасы сәркәтибе һәм мөхәррире, 1851 дән Көнчыгыш бүлеге секретаре, 1857 дән Рус һәм славян археологиясе бүлегенең эшләр башкаручысы һәм җәмгыятьнең «Известия» басмасы мөхәррире. Россия геогр. җәмгыяте әгъзасы (1847 дән). Журналистлык эшчәнлеге б-н шөгыльләнә, «Северная пчела» ж-лы, А.Плюшарның «Энциклопедический лексикон»ы, «Библиотека для чтения» ж-лы, А.Ф.Шеинның «Энциклопедический словарь» басмасы, «Литературное прибавление к «Русскому инвалиду» б-н актив хезмәттәшлек итә, аларда Якын Көнчыгыш илләре тарихы чагылыш таба. Ярославль, Владимир һәм Екатеринославль губерналарында археол. казу эшләре алып бара, славяннар, мерәләр һәм скифларга нисбәтле борынгы әйберләрне тикшерә. Хезмәтләре рус һәм Шәрекъ нумизматикасын, Алтын Урда тарихын һәм акча системасын өйрәнүгә карый. Галимнәр турында (аеруча әһәмиятлеләре — Х.М.Френ, Д.Банзаров, О.И.Сенковский турында) биографик очерклар авторы. С.ның «Рус тарихына мөнәсәбәттә ислам нумизматикасы» («Мухаммеданская нумизматика в отношении к Русской истории», СПб., 1847) монографиясе Петербург ФАнең Демидов бүләгенә лаек була.

Хезм.: Монеты юго-западных славян // Зап. Имп. Рус. археол. об-ва. 1852. Т. 9, вып. 1; Список известных доселе монет Коканского ханства // Зап. Имп. Рус. археол. об-ва. 1855. Т. 6; Монеты Джучидов, Джагатаидов, Джелаиридов и других, обращавшиеся в Золотой Орде в эпоху Тохтамыша: В 2 ч. СПб., 1857–58.

*Әд.:* Григорьев В.В. Жизнь и труды П.С.Савельева. СПб., 1861; Русский биографический словарь. СПб., 1904. Т. 18.

*А.З.Сингатуллина.*

**САВЕ́ЛЬЕВ** Павел Фёдорович (4.7.1932, Оренбург өлкәсенең Секретарский р-ны Русская Дымка а. — 9.2.2001, Әлмәт ш.), техник-механик, Соц. Хезмәт Герое (1966). Лениногорск нефть техникумын тәмамлый (1966). «Бөгелмәнефть» трестының нефть промыселларында (1949–54), «Әлмәтнефть» нефть промыселы идарәсендә (1957–61) нефть һәм газ чыгару операторы булып эшли. 1961–89 елларда «Татнефть» ЖБ «Сөләйнефть» НГДУсында: оператор, мастер, өлкән инженер, кадрлар бүлеге, инженерлык-технол. хезмәте башлыгы. Герой исеме нефть чыгару буенча 7 еллык (1959–65) планны уңышлы үтәгәне һәм нефть чыгару сәнәгате үсешенә керткән хезмәте өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Лениногорск шәһәренең Соц. Хезмәт Геройлары аллеясында С. бюсты куелган.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**САВЕ́ЛЬЕВ** Фёдор Петрович (25.12.1918, Казан губ., Чистай өязе Петропавел Бистәсе а. — 19.11.1970, Казан), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), подполковник. Казан ун-тын тәмамлый (1940). 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 696 нчы истребитель-танкка каршы артиллерия полкында батарея командиры (5 нче армия). Көньяк-Көнбатыш, Көнбатыш һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Киев оборона операциясендә (1941), Ржев–Вязьма (1943), Белоруссия (1944), Вильнюс (1944) һәм Көнчыгыш Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Дарсунишкис авылы янында Неман елгасын кичкәндә (Кайшядорис р-ны, Литва) батырлык күрсәтә: 1944 нең 17 июлендә батареяның каршы ярга йөзеп чыгуына җитәкчелек итә); дошманның берничә тубын һәм пулемётын, 2 пехота төркемен сафтан чыгара. Сугыштан соң хезмәтен Совет Армиясендә дәвам итә. 1952 дән запаста. Казанда яши. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**САВЕ́ЛЬЕВА** Любовь Ивановна (20.10.1921, Тверь өлкәсенең Завидово р-ны Фофаново а. — 15.8.2010, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1971), проф. (1973). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1944). 1947–2005 елларда Казан ун-тында, классик филол. (1957–68), рус һәм чит ил әдәбиятлары (1973–88) кафедралары мөдире. Фәнни эзләнүләре антик әдәбиятка, рус әдәбиятының антик традицияләренә карый. Хезмәтләре Марциал, Плавт, Теренций, Гораций, В.А.Жуковский, Н.И.Гнедич, А.Н.Майков иҗатларына багышлана.

Хезм.: Художественный метод П.Теренция Афра. К., 1960; Романтические тенденции в античной литературе. К., 1973; Античность в русской поэзии конца XVIII — начала XIX века. К., 1980.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**САВЕ́ЛЬЧЕВ** Алексей Петрович (18.2.1966, Тәтеш р-ны Олы Тархан а.), икътисадчы-менеджер, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007). Казан ун-тын (1989), Казан технол. ун-тын (2003) тәмамлый. 1989–92 дә Казанның спорт оешмаларында эшли. 1992–94 тә «Акции Павлова» ҖЧҖдә коммерция директоры (Чабаксар ш.), 1994–95 тә «Алма» җаваплылыгы чикләнгән ширкәттә финанс директоры (Казан). 1995–97, 1998–99 да «Спуманте-Калфорд» Россия-Венгрия уртак пр-тиесендә менеджер (Чабаксар ш.). 1997–98 дә

«Промспецресурс» ҖЧҖдә маркетинг буенча әйдәп баручы белгеч (Мәскәү). 2000–01 дә «Лориен Имидж» ҖЧҖдә үсеш буенча директор урынбасары (Казан). 2001 дә «Фосфорос» ҖЧҖ ф-лы директоры, 2005–2012 дән ген. директор (Казан). Дәүләт бүләге «Түбән-камашин» АҖдә конкурентлыкка сәләтле радиаль шиннар җитештерү технологиясен камилләштерү өчен яңа материаллар эшләгәне һәм үзләштергәне өчен бирелә. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы бар.

**СА́ВИНО** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 24 *км* көнбатыштарак, Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 47 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1583 тән Савина исеме б-н билгеле. Халкы башта Зөя Успение Богородица монастырена карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.да земство мәктәбе (1882 дә ачыла), 1 су һәм 7 җил тегермәне, йон тетү йорты, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1342 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Юмат волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1646 да — 66, 1782 дә — 85 ир-ат; 1859 да — 356, 1908 дә — 529, 1920 дә — 589, 1926 да — 550, 1938 дә — 301, 1949 да — 212, 1958 дә — 171, 1970 тә — 159, 1979 да — 103, 1989 да — 84, 2002 дә — 51 кеше.

**СА́ВИНОВ** Василий Андреевич (1770, Владимир губ. Аксёнцево а. — 1.1.1848, Казан), Казан сәүдәгәре һәм җәмәгать эшлеклесе. Ашлык һәм тимер б-н сәүдә итә, эре төзүче-подрядчы. 1821–23 елларда Казанда Җинаять эшләре мәхкәмәсе палатасында утырышчы. 1824 тә шәһәр башлыгы итеп сайлана, әмма, иске дин тарафдары булу сәбәпле, аңа башлык вазифаларын башкарырга рөхсәт ителми. 30 елдан артык Казанда иске дин тарафдарлары җәмгыяте җитәкчесе. Пыяла з-ды каршындагы скитны һәм картлар йортын үз акчасына тота, иске дин тарафдарларына акчалата ярдәм итә, аларны хөкүмәт эзәрлекләвеннән яклый, община эшләре буенча арадашчы була. С. Казан губернасының Казан өязе Кулай авылы крәстияннәрен, ирекккә чыгару максаты б-н, хуҗаларыннан сатып ала. Җәмәгать тәрбиясе приказына күп тапкырлар акчалата ярдәм күрсәткәне өчен, алтын медаль б-н бүләкләнә. С.ның картлар йортын төзекләндерүгә бирелгән акчасы *Казан шәһәр җәмәгать банкын* оештырганда файдаланыла.

*Әд.:* С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998. *Л.М.Свердлова.*

**СА́ВИНСКИЙ** посёлогы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 44 *км* көньяк-көнбатыштарак, Рамодан елгасы буенда. 2010 елда 85 кеше (чуашлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1920 еллар башында нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Спас кантоны Левашёво волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1935 нең 25 гыйнварыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1926 да — 65, 1938 дә — 75, 1949 да — 128, 1958 дә — 181, 1970 тә — 175, 1979 да — 154, 1989 да — 103, 2002 дә — 101 кеше.

**САВИНЫ́Х** Борис Владимирович (14.7.1937, Удмурт АССРның Ижевск ш. — 23.10.2003, Казан), термофизик, техник фән. д-ры (1999). 1960 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый. 1960–64 тә — Яңа Уфа нефть эшкәртү з-дында, 1964–71 дә — синтетик каучук з-дында (Казан), 1976–97 дә Бөтенсоюз чыгымнар үлчәү фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1971–75 тә һәм 1997 дән Казан технол. ун-тында җылылык техникасының теоретик нигезләре кафедрасында, каф. профессоры (2000 нән). Хезмәтләре җылылык һәм масса алмашуга, энергия саклауга, электр җиһазларын модернизацияләүгә карый. С. электр кырларының югары ешлыклы электромагнитик кырларда җылылык алмашуга һәм диэлектрик сыеклыкларны күчерүгә тәэсир итү күренешен ача; май тутырылган трансформаторларда җылылык тапшыруны интенсивлаштыру ысулын эшли, һәм бу аларның номиналь электр егәрлеген 2 тапкыр арттыру мөмкинлеген бирә.

Х е з м.: Котельные установки промышленных предприятий. Тепловой расчёт котельных агрегатов. К., 2001 (автордаш); Свойства переноса диэлектрических жидкостей и тепло-массообмен в электрических полях. К., 2002 (автордаш).

**САВИРЛА́Р** (суарлар), чыгышлары белән хәзәрләргә һәм болгарларга кардәш, төрки телле күчмә кабиләләр. 6 йөз башында Кавказ алдында яшиләр. Төньяк Кавказдагы зур хәрби көч буларак, аларны Сасанилар Ираны һәм Византия үзара көрәштә үз максатларында файдалана. 5 йөз ахыры — 6 йөз башында С. аварлар б-н сугыша. 6 йөзнең 2 нче яртысында аварлар көнбатышка күченеп киткәч, Көнбатыш Төрки каганлыкка буйсыналар. 630 елларда Төрки каганлык таркалгач, Хәзәр каганлыгы хакимлегенә күчәләр. Дагстанның диңгез буе терр-ясендә үзәк шәһәрләре Суар, Хәйдан, Җидан булган С. патшалыгы оеша. *Гарәп-хәзәр сугышлары* нәтиҗәсендә 9 йөзнең 1 нче яртысында С.ның бер өлеше Урта Идел буйларына күчеп килә һәм *Суар бәклеге* төзи, алар тарихта суарлар буларак танылa. Соңрак С. бердәм дәүләт — Идел буе Болгары оешуда җирле төрки һәм фин-угор кабиләләре б-н этносәяси бергәлек — *болгарлар* формалашуда катнаша.

*Әд.:* Г а д л о А.В. Этническая история Северного Кавказа IV–X вв. Л., 1979; История татар с древнейших времён. К., 2002. Т. 1; К л я ш т о р н ы й С.Г., С а в и н о в Д.Г. Степные империи Древней Евразии. СПб., 2005; И с х а к о в Д.М., И з м а й л о в И.Л. Этнополитическая история татар (III — середина XVI вв.). К., 2007; G o l d e n P.B. Khazar studies. Bdpst., 1980.

*И.Л.Измайлов.*

**САВО́СТИН** Сергей Геннадьевич (7.10.1961, Свердловск өлкәсенең Нейвинский р-ны Югары Нейвинский пос.), спортчы (автомобиль спорты), ТРның (1999), Россиянең (2003) атказ. спорт остасы. ТРның атказ. машина төзүчесе (2009). 1987 елда Кама автомеханика техникумын тәмамлый (Чаллы ш.). 1979 дан «КамАЗ» АҖнең фәнни-техник үзәгендә (Чаллы ш.). «Мастер-ралли» (1996, Париж–Мәскәү–Улан-Батор; 2000, Париж–Истанбул), «Чүлне буйсындыру» (1999, 2008, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре), «Париж–Дакар–Каһирә» (2000), «Оптик–2000» (2000, 2001, Тунис), «Бажа–Италия» (2000), Россия чемпионатлары этаплары (2000–01, 2003), «Аррас–Мадрид–Дакар» (2002), «Телефоника–Дакар» (2003, 2004), «Шәрекъ ралли–Каппадокия» (2003), «Шәрекъ ралли» (2003–04), «Лиссабон–Дакар» (2006), «Дакар» (2010–11, 2013) раллиларында җиңүче. Россия Кубогы (2001), Дөнья Кубоклары (1996, 2000) иясе; Йөк автомобильләре арасында ралли-марафон буенча Россия чемпионы (2000, 2012). «Мастер-ралли-95» (Париж– Мәскәү–Улан-Батор–Пекин), «Дезерт-Челлендж» (2005), «Хәзәр далалары» (2006), «Ефәк юлы – Дакар сериясе» (2010), «Сембер тракты» (2011–12) раллиларында — көмеш медальләр, «Байконур–Мәскәү» (1997) раллиенда бронза медаль ала. 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», Батырлык, Почёт, Дуслык орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы.

**СА́ВОЧКИНО** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 8 *км* көньяк-көнбатыштарак, Урман Чишмәсе елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 77 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. 19 йөзнең 1 нче чирегендә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Дынгиз исеме б-н дә билгеле. 1860 ларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 720 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Яңа Писмән волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 233, 1889 да — 461, 1910 да — 435, 1920 дә — 514, 1926 да — 580, 1938 дә — 377, 1949 да — 200, 1958 дә — 251, 1970 тә — 241, 1979 да — 139, 1989 да — 73, 2002 дә — 64 кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**САВО́ЩЕНКО** Нина Николаевна (18.1.1921, Саратов губ., Дергачи а. — 11.09.2011, Казан), спортчы, тренер (баскетбол), РСФСРның атказ. тренеры (1991). 1933 елдан Казанда. РСФСР чемпионы (1950, «Спартак» командасы составында, Казан), РСФСР беренчелекләрендә («Динамо» командасы составында, Казан) бронза (1952) һәм көмеш (1953) медальләр ала. 1937–41, 1943–46 елларда «Спартак» ирекле спорт җәмгыяте респ-ка советының чаңгы спорты һәм җиңел атлетика буенча тренер-инструкторы. 1946–64 тә «Динамо» физкультура спорт җәмгыятенең Татарстан респ-ка советында

тренер (чаңгы спорты, җиңел атлетика, баскетбол). 1964–69 да Казан үзәк стадионында инструктор. 1969–76 да 6 нчы Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә баскетбол буенча тренер. Шәкертләре арасында — В.Анастасина-Шевченко (СССРның спорт остасы, Европа чемпионы, 1952), Т.П.Пыркова-Слиденко (СССРның атказ. спорт остасы, Европа — 1962, 1964, 1966, 1968, дөнья — 1964, 1967 чемпионы), Н.Пшесмыцкая (СССРның халыкара классы спорт остасы, Европа чемпионы, 1962), Ә.Фәйзуллина, Е.Заморий (РСФСР, СССР җыелма командалары әгъзалары). Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

**СА́ВЧЕНКО** Иван Григорьевич (18.2.1862, Полтава губ. Ромны өязе — 3.10.1932, Краснодар ш.), патолог, терапевт, бактериолог, иммунолог, медицина д-ры (1895), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1928). Киев ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1888), шунда ук, проф. В.О.Подвысоцкий кул астында эшли. 1895 елда Парижда командировкада була (проф. И.И.Мечников карамагында). 1896 дан проф., Казан ун-тының гомуми патология каф. мөдире, бер үк вакытта, 1901–18 дә, Бактериология ин-ты җитәкчесе. 1903 тә ун-тта беренче тапкыр студент-медикларга бактериология укытуны оештыра. 1920 дән Кубань ун-тында (Краснодар ш.) гомуми патология каф. мөдире. Хезмәтләре патологик анатомия, этиология, патогенез, йогышлы авырулар иммунологиясенә, фагоцитоз мәсьәләсенә карый. 1905 тә үзенчәлекле гемолитик стрептококк токсинын ача һәм Бактериология ин-тында скарлатинага (кызылчага) каршы агудан арындыручы сыгынты әзерли. 1920–32 дә Краснодар химия-бактериология һәм санитария ин-тының оештыручысы һәм директоры.

Х е з м.: Острый ревматизм и бактерия Achalméa // Рус. архив патологии, клинической медицины и бактериологии. 1898. Т. 5; К биологии бактерии острого ревматизма // Рус. архив патологии, клинической медицины и бактериологии. 1899. Т. 8, вып. 2 (автордаш); Морфологические заметки по патогенезу новообразований. СПб., 1901.


*Әд.:* А р и с т о в с к и й В.М. Иван Григорьевич Савченко // Журн. микробиологии, эпидемиологии и иммунобиологии. 1948. № 9.

**САГАДЕ́ЕВ** Артур Владимирович (24.2.1931, Казан — 22.1.1997, Мәскәү), философ, шәркыятьче галим, филос. фән. д-ры (1970), проф. (1991). Мәскәү Көнчыгыш ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), Казан ун-ты Фәнни китапханәсендә эшли. 1956 елдан Мәскәүдә: 1959–70 тә СССР ФА Философия ин-тында, бер үк вакытта, 1965–70 тә, Мәскәү ун-тында. 1970 тән СССР ФАнең Иҗтимагый фәннәр буенча фәнни мәгълүмат ин-тындагы Азия һәм Африка илләре бүлеге баш фәнни хезмәткәре, бер үк вакытта, 1991–97 дә, Халыклар дуслыгы ун-тының философия тарихы каф. профессоры. Хезмәтләре классик һәм хәзерге заман гарәп-мөселман философиясенә, Якын һәм Урта Көнчыгыш илләре эстетика гыйлеменә, М.Х.Солтангалиевнең сәяси эшчәнлегенә карый. Ибне Рөшд, Ибне Сина һ.б. әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итә.

Х е з м.: Ибн-Рушд (Аверроэс). М., 1973; Ибн-Сина (Авиценна). М., 1980; Мирсаид Султан-Галеев и идеология национально-освободительного движения. М., 1990; Восточный перипатетизм. Нью-Йорк, 1999.

*Әд.:* А л е к с е е в П.В. Философы России XIX — XX столетий. М., 2002.

**САДА́К** (саадак, сайдак), атлы сугышчының җәя кынысы һәм уклар савыты. *Җәя* һәм ук б-н бер үк вакытта барлыкка килгән. Җәя кынысы махсус ук каешына — сул яктан, ук кынысы уң яктан беркетелгән. Урта гасырларда Евразия халыкларында, ш.и. Идел буе халыкларында да, 5–15 йөзләрдә «кесәле» С.лар киң таралган. С. диаметры 15–25 *см* лы агач аслыкка каен тузы яки күн б-н тышланган дүрт агач пластинка беркетеп эшләнгән. С.ның өске өлешендә, ук алуга җайлаштырып, уемтык ясалган, һәм ул махсус япма б-н капланган. Авызы янында һәм төпкә таба С. киңәебрәк торган. Ул ярымцилиндр формасында булып, эчке яктан нығытылган.



Садаклар. 13–15 йөзләр. Фарсы миниатюралары.

Биеклеге, ук озынлыгына бәйле рәвештә, 60–80 *см* тәшкил иткән. С. сирәк кенә очракларда тышкы яктан тар вертикаль сөяк пластинкалар б-н бизәлгән. Уемтык читләренә дә шундый ук пластинкалар тезелгән. Атта йөргәндә С.ны беркетү өчен каркасның агач пластинкаларына сөяк яки тимер элмәкләр, ә төбенә каешка тагылган металл ыргак беркетелгән. 13–15 йөзләрдә мондый төр С.лар тышкы яктан үсемлек һәм хайван сурәтләре төшерелгән сөяк пластинкалар тезеп эшләнгән. 15–17 йөзләрдә Евразиядә, ш.и. татар ханлыкларында да бу төр С.ларны ук очлары түбән каратып куела торган тәбәнәк күн футляр алыштыра. Урта гасырларга караган рәсемнәр буенча, С.ны бил турысында, уң якта, авыш хәлдә (ук алуны җиңеләйтү, җәяү һәм атта йөргәндә уңайсызлыклар тудырмау өчен) йөрткәннәр дип нәтиҗә ясарга мөмкин. Уклар очлары б-н түбән каратып куелган. Язма чыганакларга караганда, гадәти С. 30 ук сыйдырышлы булган, сугышчылар яуга уклар тутырылган ике С. алганнар. Зиннәтле җыелмалар көмеш һәм алтын җепләр б-н чигелгән, уеплап һәм каралтып бизәк төшереп, көмеш яки алтын йөгертелгән пластинкалар, кыйммәтле ташлар б-н бизәлгән сафьяннан эшләнгән. С. үрнәкләре Мәскәү Кремленең Кораллар палатасында һәм Дәүләт Тарих музеенда (Мәскәү) саклана.

*Әд.:* М е д в е д е в А.Ф. Ручное метательное оружие (лук и стрелы, самострел) VIII–XIV вв. М., 1966; Культура Биляра. М., 1985; А с т в а ц а т у р я н Э.Г. Турецкое оружие. СПб., 2002; Г о р е л и к М.В. Армии монголо-татар X–XIV вв. М., 2002. *И.Л.Измайлов.*

**«САДА́К»** («Ук»), рәсемле әдәби-нәфис, сатирик журнал. 1917 елның декабреннән 1918 гә кадәр Верный шәһәрендә (Төркестан АССР) аена 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә, барысы 5 саны чыга. Төркестан Берләшкән мөселман эшчеләр берлеге органы. Мөхәррире — З.*Бәшири*. Журналда төбәк хәбәрләре, агарту һәм сәяси характердагы, кеше холкындагы җитешсезлекләрне көлеп тәнкыйтьләгән материаллар басыла. Совет хөкүмәтенең большевистик булмаган барлык басма органнар эшчәнлеген туктату турындагы декреты нигезендә хөкүмәтнең җирле органнары тарафыннан ябыла.

*Әд.:* Алматы: Энцикл. Алматы. 1996.

**САДӘ́ ГОСМА́Н** (псевд., чын исем-фамилиясе Зәйнетдинов Госман Мохтасар улы) (23.2.1949, БАССРның Аскын р-ны Әмир а. — 14.1.2014, Казан), шагыйрь, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1994). Башкорт ун-тын тәмамлагач (1972), Казанга күчеп килә. «Татарстан» ж-лында тәрҗемәче (1972–79), «Сабантуй» ж-лында башта — җаваплы сәркәтип, соңрак баш мөхәррир урынбасары (1979–95) булып эшли. 1996 дан «Шәһри Казан» г-тасында әдәби хезмәткәр. Шигырьләре 1960 елларда «Башкортстан пионеры», «Кызыл таң» г-таларында, «Сәнәк» ж-лында, «Яшь көчләр» альманахында басыла башлый. «Мәхәббәт елы» (1985), «Җиләкле тәрәзәләр» (1987), «Тайфун күзе» (1990), «Ярату ява» (2009) җыентыклары авторы. Шигырьләре поэтик формаларның төрлелеге, тел-сурәтләү чараларының байлыгы, фикер-хиснең ихласлыгы, фәлсәфилеге б-н аерылып тора.

**САДИ́КОВО** (Исәлек) авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 20 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 78 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөз уртасына кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Садиловка исеме б-н дә билгеле. 1961 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне, вак-төяклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 572 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Әлки волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 16 ир-ат; 1859 да — 148, 1897 дә — 187, 1908 дә — 247, 1920 дә — 346, 1926 да — 292, 1938 дә — 158, 1949 да — 168, 1958 дә — 142, 1970 тә — 191, 1979 да — 157, 1989 да — 106, 2002 дә — 89 кеше.

**САДИ́ЛОВО** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 22 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кырлай елгасы буенда. 2010 елда 12 кеше (руслар) яши. 1646 дан Агыш исеме б-н билгеле. 1861 елгы реформа-

га кадәр халкы алпавыт крәстияннәре каталавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Троица кәшәнәсе, земство мәктәбе (1880 нәрдә ачыла), 2 җил тегермәне, тимерчелек, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1275 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Чыпчык волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1646 да — 17, 1782 дә — 67 ир-ат; 1859 да — 550, 1897 дә — 463, 1908 дә — 519, 1920 дә — 591, 1926 да — 628, 1938 дә — 628, 1949 да — 397, 1958 дә — 240, 1970 тә — 191, 1989 да — 41, 2002 дә — 9 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**САДО́ВНИКОВ** Владимир Геннадиевич (25.1.1928, Буа кантоны Шонгыт а. — 26.2.1990, Удмурт АССРның Воткинск ш.), сәнәгать җитештерүен оештыручы, ике тапкыр Соц. Хезмәт Герое (1976, 1981). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), «Южмаш» махсус КБда (Днепропетровск ш.) инженер, төркем башлыгы, әйдәп баручы конструктор. 1958–66 елларда Ижевск механика з-дында: әйдәп баручы конструктор, СКБ башлыгы, баш инженер (1960 тан). 1966–87 дә Воткинск машина төзү з-дында, 1988 дә «Воткинск заводы» ҖБдә директор. С. җитәкчелегендә Россиядә тиңе булмаган технологияләр нигезендә ракеталар җитештерү оештырыла: «һава-һава» классындагы кече ракеталар (Ижевск механика з-дында); ОТР-22 «Темп-С», ОТР-23 «Ока»; континентара стратегик — РС-14 «Тем-2С», РС-10 «Пионер», «Пионер-УТТХ», РС-12М «Тополь» тактик ракеталары илнең оборона потенциалын тәшкил итә; халык кулланышы товарларын күпләп чыгару үзләштерелә (кер юу машиналары, балалар коляскалары һ.б.). Тамырдан реконструкцияләү, пр-тиеләрне киңәйтү уздырыла, торак йортлар һәм соц.-мәдәният объектлары төзелә. Герой исеменә махсус техника җитештерүне үзләштерү һәм үрнәкләрен булдырудагы уңышлары, җитештерүдәге югары казанышлары, 10 нчы бишьеллык планнарын (1976–80) алдан үтәүне оештырганы өчен лаек була. СССР Дәүләт бүләге (1969) махсус приборлар төзелеше өлкәсендә бирелә. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар. КПССның 24 нче һәм 27 нче съездлары делегаты (1971, 1986). 1967–88 елларда Удмурт АССР ЮС депутаты. 3 Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. С. исеме Удмурт АССРның Хезмәт даны һәм батырлыгы китабына кертелә (1978). Воткинск шәһәренең мактаулы гражданы (1980); С. исеме б-н Воткинск шәһәрендә машина төзелеше техникумы, бер урам атала; заводның инженерлар корпусында (Воткинск ш.) һәм Казан техник ун-ты бинасында (1989) С.ка бюст, 3 мемориаль такта, барельефлар куелган.

*Әд.:* След на земле: Сб. статей. Ижевск, 1997; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.


**САДО́ВНИКОВ** Григорий Данилович (23.4.1912, Сембер губ., Буа өязе Чуаш Чурапаны а. — 22.7.1987, Төмән ш.), Дан орденының тулы кавалеры (29.2.1944, 20.8.1944, 29.6.1945), өлкән сержант. Ульянов пед. уч-щесен тәмамлый (1940). Туган авылында укытучы булып эшли. 1941 елның сентябреннән Кызыл Армия сафларында. 1941 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 886 нчы аерым сапёрлар батальонында отделение командиры (22 нче һәм 31 нче армияләрнең 44 нче укчы корпусы). Калинин, 2 нче Балтыйк буе һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Смоленск (1941) сугышында, Ржев-Вязьма (1943) һәм Белоруссия һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 19 февраленә каршы төндә Калинин өлкәсенең Шерово авылы янындагы сугышта батырлык күрсәтә: дошман уты астында отделениесе б-н дошманның мина кыры һәм тимер чыбыклы киртәләре аша үтәргә юл ясый, һөҗүм итүче укчы подразделениеләргә алга үтүгә булышып, танкка каршы 12 минаны зарарсызландыра; 1944 нең 10–11 августында Айвиексте елгасын кичеп, Каленава торак пункты (Плавиняс шәһәреннән төньяк-көнчыгыштарак, Латвия) янында пехотачылар б-н бергә каршы ярга чыга, дошман уты астында С. отделениесе, техника һәм пехотаны Омаца һәм Иорфат (Көнчыгыш Пруссия) елгалары аша чыгару өчен, күпергә өрлек һәм бүрәнәләр сала. Хайлигенбайль шәһәрен (Калининград өлкәсе, хәзер Мамоново ш.) штурмлаганда С. беренчеләрдән булып һөҗүмгә күтәрелә, дошманның орудиесен кулга төшерә һәм шәһәр янындагы сугышта отделениесе б-н 2 йортны ала; шушы сугышта каты яралана. 1945 тә демобилизацияләнгәннән соң, Төмәндә яши, совхозда слесарьлар бригадиры булып эшли (Красноярск крае Агинский р-ны). 1 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.


*М.З.Хәбибуллин.*

**САДО́ВЫЙ** посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 22 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сумка елгасыннан 1,5 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 273 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 71, татарлар — 26%) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Клуб. 1930 елларда нигез салына, торак пункт буларак 1959 да теркәлә. Халык саны: 1958 дә — 601, 1970 тә — 694, 1979 да — 539, 1989 да — 415, 2002 дә — 320 кеше.

**САДРЕТДИ́НОВ** Әгъләм Кыям улы (26.10.1951, Чуаш АССРның Комсомол р-ны Чичкан а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, а.х. фән. д-ры (2005), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1995). Казан а.х. ин-тын (1975), Саратов югары партия мәктәбен (1990), Казан финанс-икътисад ин-тын (2005) тәмамлый. 1976–77 елларда — Кама Тамагы р-ны Ленин исем. колхозда, 1977–79 да Апас р-ны



В.Г.Садовников.



Г.Д.Садовников.

Куйбышев исем. колхозда баш инженер. 1979–81 дә Апас машина-техника паркы управляющиеның техник хезмәт күрсәтү буенча урынбасары. 1981–87 дә — Апас «Сельхозхимия» берләшмәсе, 1987–91 дә Апас р-ны кулланучылар җәмгыяте рәисе. 1992–98 дә Халык депутатларының Апас район советы рәисе, Апас р-ны хакимияте башлыгы. 1998–2006 да Буа р-ны һәм Буа шәһәре хакимияте башлыгы, 2006–07 дә «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы. 2007–10 да ТРның экология һәм табигый ресурслар министры. Хезмәтләре терлекчелек мәсьәләләренә, а.х. җитештерүендә агроминераль чимал куллану ярдәмендә ресурсларны саклау технологияләрен гамәлгә кертү мәсьәләләренә карый. 2000–04 тә ТР халык депутаты. ТРның Фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Дуслык ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Цеолитсодержащие породы Татарстана и их применение. К., 2001 (автордаш); Агроминеральные ресурсы Татарстана и перспективы их использования. К., 2002 (автордаш); Хартия земли в Татарстане. К., 2007 (автордаш).

**САДРЕТДИ́НОВ** Фоат Заһит улы (16.8.1965, Буа р-ны Яңа Тинчәле а.), галим агроном, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997), а.х. фән. канд. (2003). Тәтеш совхоз-техникумын (1985), Казан а.х. ин-тын (1991) тәмамлый. 1985–87 дә Буа р-нының «Искра» к-зында агроном-орлыкчылык белгече. 1987–2001 дә «Татрапс» АҖдә, әйдәп баручы агроном, җитештерү бүлеге башлыгы, бер үк вакытта ген. директор урынбасары (1994 тән). 2001 дән «Тетра-Инвест» холдинг компаниясе» ҖЧҖ директоры, 2003 тән башкарма директоры (Казан). Дәүләт бүләге рапсны куллану, эшкәртү, җитештерүнең икътисади нигезләрен һәм фәнни нигезләнгән технологияләрен эшләүдә катнашканы һәм аларны гамәлгә керткәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**САДРЕТДИ́НОВ** Шәйхелислам Аләветдин улы (5.12.1936, Чүпрәле р-ны Татар Бизнәсе а. — 21.3.1996, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. канд. (1972). Казан ун-тын тәмамлый (1960), 1967–96 елларда шунда ук эшли. Фәнни эзләнүләре – 19 йөз — 20 йөз башы татар әдәбияты өлкәсендә. Хезмәтләре С.Рәмиев, Ә.Каргалый, М.Иванов иҗатларына карый. Урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен татар әдәбияты буенча дәреслекләр һәм хрестоматияләр автордашы; С.Рәмиев әсәрләрен матбугатка әзерли (кереш сүз, текстология, шәрехләүләр).



М. Садри.

Х е з м.: Сәгыйть Рәмиев иҗаты. К., 1973; Ә.Каргалый: студентлар өчен ярдәмлек. К., 1978 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**САДРИ́** (Садретдинов) Мөхәммәт Хәбибулла улы (20.5.1913, Казан — 27.3.1999, шунда ук), шагыйрь, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1983). 1921 елда ятим калып, әбисе тәрбиясендә үсә, 1927 дә балалар йортына билгеләнә. 1928 дә М.Вахитов исем. сабын кайнату з-ды каршындагы ФЗӨ мәктәбенә керә, слесарь һөнәренә өйрәнә, заводның күптиражлы «Вахитовчы» г-тасында хәбәрче булып эшли. Мәскәүдә Дәүләт театр сәнгате ин-тын тәмамлый (1935). 1941 гә кадәр ТАССР Халык комиссарлары советы каршындагы Сәнгать эшләре идарәсенең муз. фольклор кабинетында фәнни хезмәткәр. Бөек Ватан сугышында катнаша: тупчы-артиллерист, сугыш кораллары бүлеге башлыгы, транспорт башлыгы; яралангannан соң, «Ватан намусы өчен» фронт г-тасында хәрби хәбәрче. Сугыштан соң ТАССР Язучылар берлеге идарәсендә җаваплы сәркәтип. 1948 дән «Социалистик Татарстан» г-тасында хәбәрче, 1953–56 елларда әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире.

1932 дә «Җыр башлана» исемле беренче шигырьләр җыентыгы басылып чыга. Сугыш елларында җиңүгә, батырлыкка рухландырган очерклар, патриотик шигырьләр яза. «Без җырлыйбыз» (1947), «Йөрәк тибүе» (1956), «Мин Берлинны алдым» (1969) лирик шигырь җыентыклары солдат тормышына багышланган. «Бәхет турында җыр» (1948), «Гүзәл яшьлек» (1950), «Тантана» (1953), «Яз сулышы» (1962) җыентыкларына тупланган шигырь һәм поэмаларында җиңүче солдатның туган илгә әйләнеп кайту, тыныч тормыш шатлыгы мотивы өстенлек итә. С.ның респ-ка композиторлары б-н берлектә иҗат иткән җырлары халык арасында киң тарала. Балалар өчен язылган «Абыйлар һәм апалар» (1959), «Без хезмәт яратабыз» (1962), «Кышкы бакча» (1962) җыентыклары авторы. Татар теленә П.П.Ершовның «Конёк-Горбунок» («Канатлы ат», 1953; 3 нче басма 1966) әкиятен, А.С.Пушкин, В.В.Маяковский, А.Т.Твардовский, А.А.Сурков, М.В.Исаковский шигырьләрен тәрҗемә итә. Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н; ике тапкыр ТАССР ЮС Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайра, сандугач! К., 1967; Гасыр җыры. К., 1983; Иртешкә сәяхәт. К., 1989; Планета на рассвете. М., 1979.

**САДРИ́** (Садретдинов) Халикъ (Габделхаликъ) Гариф улы (4.8.1890, Самара губ., Богырыслан өязе Иске Ярмәк а. — 8.3.1955, Казан), язучы. Окт. рев-циясендә, Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. Уфа мәдрәсәсендә укый (1912–15), Татар коммунистлар ун-тын тәмамлый (1928). 1919 елда РКП(б)ның 2 нче Бөтенроссия съездына делегат итеп сайлана, делегация составында В.И.Ленин б-н очраша, 1919–22 дә РКП(б)ның Самара губерна ком-тында татар секциясен җитәкли. 1928–30 да Казанның «Спартак» аяк киемнәре ф-касында, 1930–38 дә Бөтенсоюз уйлап табу һәм хезмәтне рациональләштерү буенча өлкә советы рәисе. 1946–55 тә — СССР әдәби фондының Татар бүлеге рәисе. Беренче язмалары матбугатта 1912 дә күренә башлый. Шигырь, пьеса, очерк, хикәя жанрларында җат итә. «Кечкенә һөнәрләр» (1915), «Ил батырлары» (1935), «Тимерче малае» (1936, рус теленә тәрҗемәсе «Сын кузнеца», 1953) повесть һәм хикәяләр җыентыклары, «Безнең таң» (1937) романы авторы. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2. *Н.И.Таиров.*

**САДРИ́ЕВ** Дөфәр Сабир улы (18.9.1941, Дүшәнбе ш., Таҗикстан ССР), икътисад өлкәсе галиме, икътисад фән. д-ры (2001), проф. (2002). Таҗик ун-тын тәмамлый (1972). 1965–90 елларда Дүшәнбедә: пасс. транспорты берләшмәсендә, 1972–74 тә Таҗик политехник ин-тында, 1974–82 дә «Автотранссистема» җитештерү-техник берләшмәсендә сектор мөдире, бүлек мөдире, 1982–86 да СССР Фән һәм техника дәүләт ком-ты каршындагы Бөтенсоюз оештыру һәм идарә проблемалары фәнни-тикшеренү ин-тының Таҗикстан ф-лында бүлек мөдире, 1986 дан Таҗикстан ССР Дәүләт план ком-тының Икътисад һәм планлаштыруның икътисади-матем. ысуллары фәнни-тикшеренү ин-тында бүлек мөдире. 1990 нан Кама политехник ин-тында (хәзер Казан ун-тының Чаллы ин-тында), икътисад ф-ты деканы (1997–2007), икътисад, идарә итү һәм логистика каф. мөдире (2007–2013), логистика һәм маркетинг каф. профессоры (2013 тән). Хезмәтләре автотранспорт комплексы б-н системалы-синергетик һәм базар мөнәсәбәтләре шартларында мөстәкыйль оешу ысулларын кулланып идарә итү мәсьәләләренә карый. Шәһәрләр, төбәкләр, респ-калар арасында транспорт-икътисад элемтәләрен; идарә итүнең, тармак һәм пр-тиеләр икътисадының, маркетингның заманча формаларын тикшерә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем хезмәткәре.

Х е з м.: Экономика автомобильного транспорта. Наб. Челны, 1997; Организация и управление на автомобильном транспорте в условиях кризиса. Наб. Челны, 1999; Управление грузовым автотранспортным комплексом. Системно-синергетический подход. СПб., 1999; Экономика отрасли. Наб. Челны, 2005.

*Әд.:* Энциклопедия города Набережные Челны. К., 2007.

**САДРИ́ЕВ** Исхак Әюп улы (9.8.1946, Яңа Писмән (хәзер Лениногорск) р-ны Чыршылы а.), хакимият-хуҗалык хезмәткәре. Саратов югары партия мәктәбен (1986), Казан техник ун-тын (2000) тәмамлый. 1962 елдан Лениногорск р-нында: «Коммунизмга» (1977 гә кадәр) с-зында, 1977–79 да КПСС шәһәр ком-ты инструкторы, 1979–88 дә Мичурин исем. к-з рәисе, 1988–90 да «Глазовский» с-зы директоры, 1990–91 дә башкарма ком-т рәисе, 1991–95 тә халык депутатларының район советы рәисе. Бер үк вакытта, 1992–2006 да, Лениногорск р-ны һәм Лениногорск шәһәре хакимияте башлыгы; 1995–2006 да Лениногорск берләштерелгән халык депутатлары советы рәисе. 2006–09 да «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы. 1990–95 тә ТР ЮС депутаты, 1995–2004, 2009–14 тә ТР халык депутаты. Почёт ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**САДРИ́ЕВ** Линар Гыйльман улы (2.10.1937, Апас р-ны Ябалак а. — 27.12.1999, Казан), режиссёр, ТССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991). Ленинград театр, музыка һәм кинематография ин-тын тәмамлый (1966). 1956 елдан Татар респ-ка күчмә театры актёры, 1966–70 тә режиссёры; «Умырзая» (В.Сәйфуллин), «Шамакай» («Затейник», В.Розов), «Тынгысыз төн» (Г.Мөхәммәтшин), «Мәйсәрә хәйләләре» (Х.Ниязи), «Мәхәббәт турында җыр» (Ә.Атнабаев), «Шамил» (Р.Ишморатова) спектакльләрен куя. 1970–73 тә Казан телестудиясе режиссёры. 1973–75 тә Әлмәт татар драма театрының баш режиссёры, аның сәхнәсендә «Рәйхан» (Н.Исәнбәт), «Таң әтәче кычкырганчы» («Пока не пропел петух», И.Буковчан), «Үлмәс җыр» (Р.Ишморат), «Җан җылысы» (А.Гыйләҗев) спектакльләрен куя. 1980–92 дә Минзәлә татар драма театры актёры һәм режиссёры. С.ның бу чордагы спектакльләре арасында яшь драматургларның татар театры репертуарында лаеклы урын алган пьесалары буенча куелганнары аерым игътибарга лаек: «Бер яшьлектә, бер картлыкта», «Сары чәчәк саплары» (Ә.Гаффар), «Оҗмах балалары», «Моңнар төште башыма» (М.Маликова), «Һәркемгә бер кояш» (Ф.Бәйрәмова), «Пар канатлар» (Ю.Сафиуллин), «Кызлар күңеле — тирән сер», «Мәхәббәт яңгыры» (Ф.Яруллин), «Исемсез утрау» (М.Галиев) һ.б. 1992 дән Казан татар яшь тамашачылар театрында: Вурм («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), Лапшин («Шау-шулы көн», В.Розов), Сәлим бай («Помада мәсьәләсе», И.Богданов) рольләрен башкара; И.Юзеевның «Хуш, Хәйбуш», Р.Корбанның «Керпе малае дуслар эзли», Ф.Яруллинның «Бер көрешү — үзе бер гомер» әсәрләре буенча спектакльләр куя. С. режиссурасы спектакльләрне сәхнәгә куйганда — ихласлык, комедия һәм драма жанрларында — лирик көнкүрешкә якынлык, характер һәм ситуацияләрне бергәндә тормыш чынбарлыгына тугрылык б-н аерылып тора.

*Әд.:* Г ы й м р а н о в а Д.Ә. Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры. К., 2007. *Д.Ә.Гыймранова.*

**САДРИ́ЕВ** Самат Сәлах улы (1920, Самара губ., Бөгелмә өязе Иске Шөгер а. — гыйнвар 1988, Лениногорск р-ны Подлесный бистәсе), Сов. Союзы Герое (3.6.1944), старшина. Финанс бүлегендә статист булып эшли. 1942 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 667 нче укчы полкның отделение командиры (47 нче армиянең 218 нче укчы дивизиясе). Воронеж, 1 нче Украина һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Белгород–Харьков (1943), Люблин–Брест (1944) һәм Варшава–Познань (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Днепр елгасын кичкәндә Хутор-Хмельная (Черкассы өлкәсе Канев р-ны) авылы янында батырлык күрсәтә: 1943 нең 24 сентябрендә беренчеләрдән булып елганы йөзеп чыга; С. җитәкчелегендәге отделение плацдармны яулап ала, полкның укчы подразделениеләренә елга аша чыгуны һәм икенче ярда ныгуны тәэмин итә. 1946 елда демобилизацияләнә. «Лениногорскнефть» НГДУында электр б-н эретеп ябыштыручы, машинист булып эшли. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 1 нче дәрәҗә (ике тапкыр) һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.
*М.З.Хәбибуллин.*

**САДРИ́ЕВ** Фоат Миңлеәхмәт улы (10.3.1941, Мөслим р-ны Олы Чакмак а.), язучы, драматург. ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991), ТРның халык язучысы (2014). Казан ун-тын (1965), Дәүләт театр сәнгате ин-ты каршындагы Югары театр курсларын (Мәскәү, 1982) тәмамлый. 1963–70 елларда Сарман («Сарман») һәм Мөслим («Авыл утлары») р-н г-таларында әдәби хезмәткәр. 1970–72 дә Лаеш а.х. техникумының Мөслим авылындагы укыту-консультация бүлеге мөдире. 1972–81 дә «Авыл утлары» г-тасы мөхәррире. 1992–96 да Мөслим үзәк китапханәсе директоры. «Оҗмах ишеге төбендә» (1970) исемле беренче пьесасы дөнья күргәч, аның Әлмәт, Минзәлә, Оренбург татар драма театрлары б-н актив хезмәттәшлеге башланып китә. Бу театрлар сәхнәсендә С.ның «Их сез, егетләр!» (1976 да куела), «Ач тәрәзәң» (1978), «Кондырлы кодачасы» (1981 дә куела), «Тозлы бал» (1988), «Аяз көнне яшен» (1989), «Яшьләй сөйгән ярлар» (1991), «Безнең гомер язлары» (2001), «Тәрәзәгә егет килгән» (2008) пьесалары буенча спектакльләр уйнала. Повесть һәм хикәяләре тупланган «Шаһзаманов эше» (1989), «Адәм әүлиясе» (1997), «Көлми торган кеше» (2004) җыентыклары авторы. Әсәрләрендә С. чынбарлыктагы тискәре күренешләрдән көлә, ялагай, комсызларның сатирик образларын тудыра, уңай геройларның характерларын юмор б-н сурәтли. «Таң җиле» (1993) романы сугыш һәм аннан соңгы авыр еллар кичергән өлкән буын хатын-кызларга багышлана. «Бәхетсезләр бәхете» (1–3 т., 2001–07) роман-трилогиясе тоталитар режим шартларындагы шәхес фаҗигасен ачып бирә. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2010).

Ә с ә р.: Безнең гомер язлары. К., 2005.

*Әд.:* Ә х м ә д у л л и н А. Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. К., 1980; Г а л и м у л л и н Ф. Гыйбрәтләр алсак иде... // Казан утлары. 1993. № 1; Мәйдан: Махсус чыг. 2004. № 2.

**САДРИ́ЕВА** Зәйнәп Садретдин кызы (25.11.1912, Әстерхан ш. — 31.10.1991, Үзбәкстан ССР, Ташкент), драма актрисасы, Үзбәкстан ССРның халык артисты (1952). Сәхнә эшчәнлеген Ташкенттагы Эшче күчмә театрында башлый, 1932 дән Хәмзә исем. Үзбәк акад. драма театры актрисасы. С., киң иҗат диапазонына ия актриса буларак, трагедия масштабындагы шактый гына зур рольләр башкара: Гертруда («Гамлет», У.Шекспир), Тәңкәбикә («Ай тотылган төндә», М.Кәрим), Кручинина («Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский), Любовь Яровая (К.А.Тренёвның шул исем. әсәре буенча), Васса Железнова (М.Горькийның шул исем. әсәре буенча). Актриса башкаруында Татьяна («Мещаннар», М.Горький), фрау Миллер («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), Огулхан («Хөррият», Уйгун), Харитонова («Диңгездәгеләр өчен», Б.А.Лавренёв) кебек драматик характерлар тирән психологизм б-н сугарыла. С. тарафыннан иҗат ителгән Галимә («Хаҗи әфәнде өйләнә», Ш.Камал), Фәрманбиби («Кәләшләр фетнәсе», С.Әхмәд), Хөлнисә («Ефәк сөзәнә», А.Каххар), Агафья Тихоновна («Өйләнү», Н.В.Гоголь), Феклуша («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский) кебек комик образлар буяулар куелыгы, социаль характеристиканың үткенлеге б-н аерылып тора. Үзбәкстан ССРның Хәмзә исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1967).

*Әд.:* Театральная энциклопедия. М., 1965. Т. 4; Ж а л я л е т д и н о в а М. Зайнаб Садриева. Таш., 1987.
*И.И.Илялова.*

**САДРИҖИҺА́НОВ** (1949 елга кадәр Старҗиһанов) Җәлал Гаяз улы (21.1.1909, хәзер Казакъстан Респ-касы Уральск ш. — 14.2.1997, Казан), дирижёр, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1944), РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1978). Н.Г.*Җиһановның* абыйсы. 1940 елда Мәскәү консерваториясен дирижёрлык буенча (Г.А.Столяров классы) тәмамлый. 1940–70 тә Татар опера һәм балет театры дирижёры. Н.Җиһановның «Алтынчәч» (1 нче редакция, 1941; 2 нче редакция, 1956), «Илдар» (1942), «Түләк» (1945), «Намус» (1950), С.Сәйдәшев һәм А.Ключарёвның «Наёмщик» (1962) операларының; Н.Җиһановның «Зөһрә» (1946), А.Ключарёвның «Тау әкияте» (1951), Ә.Бакировның «Алтын тарак» (1957), Р.Гобәйдуллинның «Кисекбаш» (1959) һ.б. балетларының беренче куелышларында катнаша. Симф. концертлар б-н дирижёрлык итә. 1945–71 дә — Казан консерваториясендә, 1970–87 дә Казан пед. ин-тында укыта (1970–79 да җыр һәм аны укыту методикасы каф. мөдире).



Җ.Г. Садриҗиһанов.

Ә с ә р.: Воспоминания. К., 1985; В мире музыки. К., 1990.
*Ф.Ш.Салитова.*



С.С. Садриев.



Ф.М. Садриев.

**САДЫ́ЙКОВ** Альфред Фәйзрахман улы (6.8.1953, Казан), инженер-механик. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002), техник фән. канд. (2004), ТРның атказ. машина төзүчесе (2002). Казан авиация ин-тын (1976), РФ Хөкүмәте каршындагы Халык хуҗалыгы академиясен (1992) тәмамлый. 1976 елдан «ТатНИИнефтемаш» АҖдә, директор (1989 дан), ген. директор (1995 тән). Хезмәтләре нефть машиналары төзү өлкәсенә карый. С. авиацион газ-турбина двигателе базасында катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру өчен эчке скважина җиһазлары һәм су җылыту җайланмалары, нефть-газ катнашмаларын транспортлау өчен мультифазалы насос-компрессорлар һ.б.ны эшләүдә катнаша. Дәүләт бүләге ТРда иске автомобиль шиннарын утильләштерү җайланмасын гамәлгә кертүгә өчен бирелә. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге лауреаты (1982). СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә. РФ Ягулык һәм энергетика министрлыгының мактаулы нефтьчесе.

Х е з м.: Метод расчёта энергетических характеристик и проектирование двухвинтовых насос-компрессоров для перекачивания нефтегазовых сред. К., 2002; Двухвинтовые насос-компрессоры. К., 2004 (автордаш).

**САДЫ́ЙКОВ** Әнил Мирзагаян улы (18.2.1927, Алма-Ата — якынча 1992, шунда ук), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1982). Әзәрбайҗан индустрия ин-тын тәмамлый (1949), шунда ук укыта (1950–53). 1953–92 елларда Казакъстан ФАнең Геология фәннәре ин-тында, геол. тикшеренүләр тарихы һәм методикасы лаб-ясе мөдире (1965 тән), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1987 дән). Хезмәтләре Казакъстан терр-ясенең стратиграфиясе һәм палеонтологиясенә, геология тарихы һәм методологиясенә карый. С. яңа фәнни формация — стратиграфия юнәлешен эшли, палеозой моллюсклары нигезендә Казакъстан терр-ясенең геол. датасын билгели. «СССРның геологик өйрәнелүе» томнарының берсенең («Геологическая изученность СССР», 40 т., 1–2 кис., «Южный Казахстан», М., 1986–88) мөхәррире. Медальләр, Казакъ-

стан ССР ЮСның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Идеи рациональной стратиграфии. А.-А., 1974.

*Әд.:* Казахская ССР: Краткая энцикл. А.-А., 1989. Т. 3.

**САДЫ́ЙКОВ** Бәһрам Газиз улы (3.10.1930, Казан — 10.3.2002, шунда ук), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (1975), проф. (1978), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (1991), ТРның атказ. табибе. Проф. П.В.Маненков шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1955), 3 нче Респ-ка клиник хастаханәсендә эшли. 1959 елдан Казан мед. ин-тының 1 нче акушерлык һәм гинекология кафедрасында, 1984–95 тә 2 нче акушерлык һәм гинекология каф. мөдире. Хезмәтләре йөклелек вакытындагы катлаулы иммуноконфликтка, иммунологиягә, катлаулы йөклелек очрагындагы микроциркуляциягә, яңа туган балаларда гемолитик авыруны өйрәнүгә карый. Респ-ка иммуноконфликтлы йөклелек үзәген оештыручы һәм җитәкчесе (1969–2002). Респ-ка акушер-гинекологлар фәнни җәмгыяте рәисе (1977–2002). Халыкара репродукция иммунологиясе ассоциациясе әгъзасы (АКШ, 1984). «Резус- һәм АВО-конфликтлы йөклелек» («Резус- и АВО-конфликтная беременность») хезмәте өчен ТР Дәүләт бүләге бирелә (1998). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Гемолитические заболевания перинатального периода. К., 1977 (автордаш); Родовые травмы и повреждения новорождённых. Воронеж, 1982 (автордаш); Вопросы перинатологии. К., 1991 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Бахрам Газизович Садыков // Казан. мед. журн. 1990. № 6.

**САДЫ́ЙКОВ** Зөфәр Бари улы (26.4.1938, Төрекмәнстан ССРның Ташауз өлкәсе Куня Үргәнеч штп), машиналар төзү технологиясе өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1992), проф. (1995), ТАССРның атказ. уйлап табучысы (1988). 1962 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Киров шәһәренең машиналар төзү з-дында эшли. 1965–70 тә Казандагы «Электроприбор» з-дында, технол. бюросы башлыгы (1966–68), цех башлыгы урынбасары (1968–70). 1970–92 дә Технология фәнни-тикшеренү ин-тының база лаб-ясе башлыгы (Саратов ш.). 1993–2000 дә «Электрохимик эшкәртү технологиясе» фәнни-җитештерү пр-тиесе директоры (Казан). 2000 нән Казан техник ун-тында, стандартлаштыру, сертификация һәм технол. менеджмент каф. мөдире (2000–07), каф. профессоры (2007 дән). Хезмәтләре детальләрне электрохимик эшкәртү алымнарына карый. С. детальләрне электралмаз юл б-н эшкәртүнең, адаптив идарә системасы ярдәмендә үлчәнешле электрохимик эшкәртүнең технологиясен һәм җиһазларын эшли.ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы заказы буенча мед. инструментлары (96 исемдә) булдыра һәм аларны сериялап җитештерүне оештыра. Детальләрне электрохимик эшкәртү һәм контроль-үлчәү техникасы өчен станоклар эшли (ТР Дәүләт бүләге, 1996). Уйлап табуга 47 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. РФ Космонавтика федерациясенең К.Э.Циолковский исем. медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Технологические вопросы электрохимической размерной обработки деталей. Саратов, 1973 (автордаш); Электрохимическое маркирование деталей. М., 1983 (автордаш); Управление процессом комбинированной электроалмазной обработки высокотвёрдых материалов // Вестн. Казан. техн. ун-та. 2007. № 1 (автордаш); Исследование структурной стабильности сплава ЭП-702, оптимизация термообработки сплава на максимальные упругие свойства // Вестн. Казан. техн. ун-та. 2007. № 2 (автордаш).

**САДЫ́ЙКОВ** Зөфәр Мазһар улы (20.9.1946, Казан), төзүче-инженер, ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2012). Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), «Татинвестгражданпроект» дәүләт унитар пр-тиесе архит-ра-планлаштыру остаханәсе конструкторы, баш конструкторы (1988– 2012). Дәүләт бүләге Казан Кремлендә Колшәриф мәчете ансамблен төзүдә катнашканы өчен (1997–2005; автордаш, проект чишелешенең баш конструкторы) бирелә.

**САДЫ́ЙКОВ** Ибраһим Вәли улы (22.9.1925, Тәтеш кантоны Келәш а.), галим агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. агрономы (1983). Колхоз рәисләрен әзерләүче Татарстан а.х. урта мәктәбен (1953), Казан а.х. ин-тын (1962) тәмамлый. 1938–92 елларда Тәтеш р-нында: агротехник (1950 дән), «Азат» (1953 тән), «Путь Ильича» (1959 дан) к-злары рәисе. С. җитәкче булганда, «Путь Ильича» к-зында 3,5 мең баш мөгезле эре терлек өчен бина, 2 мәктәп, балалар бакчасы, 2 тегермән, 13 *т* сыешлы ашлык амбары һәм 30 дан артык социаль-мәдәният һәм көнкүреш биналары төзелә. 1986–90 да, 1966–70 еллар б-н чагыштырганда, хуҗалыкның энергия егәрлеге – 1,7 тапкыр, ит җитештерү — 2,4, шикәр чөгендере 1,7 тапкыр арта; бөртекле культураларның уңышы — 1,3, шикәр чөгендере — 1,8, тулай продукт бәясе 1,5 тапкыр арта; хуҗалыкның табышлылык дәрәҗәсе 29,9% ка җитә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1970–74 тә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының 3 мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**САДЫ́ЙКОВ** Илгиз Фатих улы (31.10.1931, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1992), проф. (1994), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1996), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2003). 1955 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (бүленеп: 1958–62 дә Ленинград технол. ин-тында). Хезмәтләре махсус химиягә карый. С. тиз үтә торган процессларда характеристикалары төрле дәрәҗәдә булган энергия сыешлы каты материаллар булдыруның фәнни-техник нигезләрен эшли. Аз дебитлы нефть скважиналарының җитештерүчәнлеген күтәрү өчен экспресс-технологияләр комплексын (термик, термоимплозион, перфорацион-имплозион), ш.у. скважиналарны термогазкислоталы-имплозион ысул һәм каты ягулыкта эшли торган импульслы басымнар генераторы б-н эшкәртү технологиясен тәкъдим итә. Уйлап табуга 70 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997). Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Прикладная физика взрыва. М., 1983 (автордаш); Экспресс-технологии добычи нефти // Науч. Татарстан. 1997. № 2 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000; Специалисты по взрывчатым материалам, пиротехнике и боеприпасам: Биогр. энцикл. М., 2006.

**САДЫ́ЙКОВ** Илдус Харис улы (28.11.1932, Красноярск краеның Төньяк Енисей р-ны Вельмо-2 пос. — 23.9.2001, Казан), дәүләт эшлеклесе. Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1955). 1955–66 елларда Казан резина-техник эшләнмәләр з-дында эшли: механик, цех башлыгы, баш инженер урынбасары, завод ком-ты рәисе, партия ком-ты секретаре, баш инженер. КПССның Казандагы Идел буе район ком-ты (1966–69), КПССның Түбән Кама шәһәр ком-ты 1 нче секретаре (1969–82). 1982–85 тә ТАССР МС рәисе. 1985–91 дә Бөтенсоюз углеводород чималлары фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. 1991 дән Татарстан-Швейцария уртак пр-тиесе ген. директоры. 1967–90 да ТАССР ЮС, 1980–90 да РСФСР ЮС депутаты. Октябрь Революциясе, ике Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**САДЫ́ЙКОВ** Илдус Хәбибрахман улы (11.3.1940, Казан), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997), РФнең мактаулы химигы (2002). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), Л.Я.Карпов исем. Бондюг химия з-дында (хәзер Л.Я.Карпов исем. химия з-ды) эшли. 1968 елдан Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында, баш инженер (1970 тән). Дәүләт бүләге җитештерү процессында һәм һәлакәт очрагы шартларында кешене агулы, агрессив матдәләр һәм җылылык факторлары тәэсиреннән комплекслы саклау чаралары системасын эшләүдә һәм сериялап чыгаруны оештыруда катнашканы өчен бирелә. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә.

**САДЫ́ЙКОВ** Инсур Һади улы (1.1.1942, Арча р-ны Яңа Кенәр а. — 6.1.2003, Чаллы), автоматлаштырылган системалар өлкәсе галиме, югары белем системасын оештыручы, техник фән. канд. (1970). Казан. авиация ин-тын тәмамлый (1965), шунда ук гамәли матем. кафедрасында эшли, бер үк вакытта хисаплау һәм идарә системалары ф-ты деканы (1978–83). 1985–2003 елларда Кама политехник ин-тында (Чаллы): ректор (1985–96), гамәли матем. һәм информатика каф. мөдире (1996 дан). Хезмәтләре автоматлаштырылган системалы тикшеренүләр һәм сынауларның матем. тәэмин ителешенә карый. С. институтны аякка бастыруга һәм үстерүгә, фәнни-пед. эшне оештыруга зур өлеш кертә. Аның җитәкчелегендә институтның матди-техник базасы булдырыла, укыту-лабораторияләр корпусы, тулай тораклар, спорт комплексы һ.б. объектлар төзелә.

Х е з м.: Математическое обеспечение автоматизированных системных исследований и испыта-

ний двигателей внутреннего сгорания. М., 1995 (автордаш); Математическое моделирование систем массового обслуживания. Наб. Челны, 1999.

**САДЫ́ЙКОВ** Камил Сәмигулла улы (3.1.1949, Түбән өлкәсенең Ялутор р-ны Осиново а.), вакуум техникасы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1998). 1973 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, «Вакуummаш» фәнни-тикшеренү һәм конструкторлык ФҖБдә эшли, директор (2000–03). 2004 тән «Унивак-Н» фәнни-җитештерү пр-тиесенең ген. директоры. Хезмәтләре углеводородларның вакуумдагы җылылык-газ динамикасына карый. С. вакуумлы системаларда нафтен-парафинлы углеводород парларының үзлекләрен тикшерә һәм диагностика үткәрә. Парларның тавыш тизлегеннән югары агымнарын исәпләү методикасын тәкъдим итә, агымлы вакуум насослар конструкцияләрен эшли. Диффузион вакуум насослары һәм вакуум барлыкка китерә торган системалар «Казаноргсинтез», «Түбәнкаманефтехим» нефть эшкәртү пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән. Уйлап табуга 17 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Диаграмма энтальпия-энтропия вакуумного масла ВМ-1 // Вопр. атомной науки и техники. Сер. Общая и ядерная физика. 1985. Вып. 1; Сквозной расчёт диффузионного вакуумного насоса // Тез. докл. 11 Всесоюз. конф. по динамике разреженных газов. Л., 1991 (автордаш); Investigation of the diffusion pump // Vacuum.1990.V. 41, № 7–9.

**САДЫ́ЙКОВ** Марат Борис улы (10.10.1932, Мәскәү өлкәсе Дмитров ш. — 30.10.2009, Казан), философ, филос. фән. д-ры (1979), проф. (1982), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1989). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1955), ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында эшли. 1959 елдан Казан ун-тында, филос. каф. мөдире (1980–99). Хезмәтләре социаль философиягә, милләтара мөнәсәбәтләргә, мәгариф философиясенә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Единство интернациональных и национальных интересов в советском многонациональном государстве. К., 1975; Социальная философия как наука и учебная дисциплина. К., 1994. Казанский университет на пороге третьего тысячелетия. К., 1998.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. 2004. Т. 3.

**САДЫ́ЙКОВ** Марат Наил улы (27.1.1970, Буа ш.), терапевт, сәламәтлек саклау өлкәсе оештыручысы, мед. фән. канд. (1999), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2013), ТРның атказ. табибе (2013). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1994), 2 нче Респ-ка клиник хастаханәсендә эшли. 1996 елдан Казан шәһәре 18 нче клиник хастаханәсе баш табибе урынбасары. 2000 нән Казан шәһәре онкология хастаханәсе баш табибе, 2008 дән Казан шәһәре 7 нче клиник хастаханәсе баш табибе. Хезмәтләре ТРда яшәүчеләрнең репродуктив халәтен өйрәнүгә карый.

**САДЫ́ЙКОВ** Марат Фәйзи улы (1.1.1945, Үзбәкстан ССРның Бохара өлкәсе Гиждуван пос.), график, Үзбәкстанның атказ. сәнгать эшлеклесе (1999), Үзбәкстан СА академигы (2003). Оренбургтагы татар сәүдәгәрләре Сәлимовлар нәселеннән. Ташкент сәнгать ин-тын тәмамлый (Н.М.Кузыбаев остаханәсе, 1973). 1973–83 елларда П.П.Беньков исем. Ташкент сәнгать уч-щесендә укыта. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1974). Үзбәкстандагы Яшь рәссамнар берләшмәсе рәисе (1976–88), СССР Рәссамнар берлеге идарәсе әгъзасы (1988–92). Үзбәкстандагы «Ил» татар рәссамнары оешмасына нигез салучы һәм оешманың рәисе (1996). Ташкентта яши.

С. — станлы графика өлкәсендә, башлыча, акварель техникасында эшләүче әйдәп баручы рәссамнарның берсе. Шулай ук темпера, гуашь, автолитография алымнарына да мөрәҗәгать итә. Ил буйлап күп сәяхәт кыла («Кижи» (1973), «Әрмәнстан буйлап» (1983) пейзажлар серияләре), чит илләрдә була (Польша, Италия, Австрия, Германия, Франция шәһәрләре һәм ландшафтлары күренешләре сериясе). Станлы картиналар («Газли», 1975, «Сусыз даланы үзләштерү», 1974–77), публицистик эчтәлекле («Вакыйга» триптихы, 1977; «Мондый хәл булырга тиеш түгел», 1979; «Хроника-82») һәм көнкүреш жанрына караган («Уйланулар», «Кич. Бохара», «Цирк» (барысы да — 1980); «Җыен» сериясе (1985); «Үзбәкстан буенча» (1984–87); «Көн азагы» (1986); «Җылы кич» (1999) сериясе) әсәрләр авторы. С. акварельләренең төп мотивы — Бохара пейзажлары («Ак Бохара» (1979); «Минем Бохарам» (1982–86); «Үткәндәге киләчәк» (2004) серияләре); символик эчтәлекка ия («Канатта йөрүчеләр», 1995–1997) композицияләр. Әсәрләргә фәлсәфи образлылык, сыгылмалы ритмнар б-н өртелгән йомшак төсләр палитрасы, гармонияле пропорцияләр б-н яктыртылган сәнгать формаларының төгәллеге хас.



1



2

М.Ф. С а д ы й к о в. 1. «Бохара күренеше». Картон. Темпера. 1980. Шәрекъ халыклары сәнгате музее. Мәскәү; 2. «Кич. Бохара» сериясеннән. Кәгазь. Акварель. 1985. Дәүләт Третьяков галереясы.

Респ-ка һәм бөтенроссия (1972 дән); бөтенсоюз (1973 тән), ш.и. акварель (Мәскәү, 1978, 1980, 1987; Баку, 1984), эстамп (Мәскәү, 1982), графика (Мәскәү, 1985); халыкара китап күргәзмәләрендә (Берлин, Германия, 1977), «Үзбәк гравюрасы» (Париж, Лиссабон, Багдад, Гаага, Токио, Африка, Лондон һ.б. чит ил шәһәрләрендә, 1978); Үзбәкстанның «Ил» татар рәссамнары күргәзмәләрендә (Казан, 1999) катнаша. Шәхси күргәзмәләре Сиэтл, Вашингтон (АКШ, икесе дә — 1985), Ташкент (1987, 1995, 1998), Бохара (Үзбәкстан, 1989, 1995, 1997), Гиждуван (Үзбәкстан, 1990). Хельсинки (Финляндия, 1991, 1992), Нью-Йорк (АКШ, 1999), Бранденбург (Германия, 2000), Астана (Казакъстан, 2006) шәһәрләрендә үткәрелә.

Әсәрләре Дәүләт Третьяков галереясында, Шәрекъ халыклары сәнгате музеенда (Мәскәү), Дәүләт сәнгать музеенда (Ташкент), «Казан» милли мәдәният үзәгендә, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда; муниципаль һәм шәхси тупланмаларда саклана. Үзбәкстан ССРның Ленин комсомолы бүләге (1979), Үзбәкстан ССРның Хәмзә исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1986). Үзбәкстан СА дипломы б-н бүләкләнә (2002).

*Әд.:* М ю н ц М.В. Марат Садыков. Таш., 1988; З и г а н ш и н а Н.А. Марат Садыков. М., 1991.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**САДЫ́ЙКОВ** Наил Сәлах улы (19.3.1941, Буа ш.), социаль гигиена белгече, сәламәтлек саклау өлкәсе оештыручысы, ТАССРның, РФнең атказ. табибе (1987, 2002). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1967), Төркмәнстан ССР мед. учреждениеләрендә эшли. 1968 елдан Буа үзәк район хастаханәсе баш табибе урынбасары. 1972 дән — Буа мед. уч-щесе, 1981 дән Казан мед. уч-щесе директоры. 1989–2003 тә ТР сәламәтлек саклау министры урынбасары. 2003 тән Респ-ка мед. китапханә-мәгълүмат үзәге директоры урынбасары. СССР Сәламәтлек саклау отличнигы (1978).

**САДЫ́ЙКОВ** Нариман Солтан улы (2.9.1940, Буа ш.), вет. табибе, микробиолог, вет. фән. д-ры (1995), проф. (2006), ТРның атказ. табибе (1998). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1969), Буа р-нының «Гигант» к-зында баш. вет. табибе булып эшли. 1972 елдан Хайваннарның токсикология һәм радиация куркынычсызлыгы буенча федераль үзәктә (2004 кә кадәр — Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-ты), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1996 дан), штаммнар музее лаб-ясе мөдире (2006 дан). Фәнни тикшеренүләре а.х. терлекләрендә очрый торган йогышлы авырулар б-н көрәш чаралары һәм ысулларына карый. Уйлап табуга 14 авторлык таныклыгы һәм 3 патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Профилактика бруцеллёза и сибирской язвы сельскохозяйственных животных на современном этапе // Тр. 2 съезда ветеринарных врачей Республики Татарстан (23–25 мая 2000 г.). К., 2001.
*Әд.:* С у н г а т о в В. Академия жизни. К., 2006.

**САДЫ́ЙКОВ** Равил Касыйм улы (1.10.1951, Казан), геолог-икътисадчы, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995), геогр. фән. канд. (1985). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1974), ЦНИИгеолнерудта эшли, директор урынбасары (2001 дән). С. металл булмаган файдалы казылма ресурсларны геол.-икътисади яктан бәяләү алымын (И.Л.Шаманский, Н.С.Чуприна һ.б. б-н берлектә) эшли, аның нигезендә РФ субъектлары терр-ясендә металл булмаган казылмаларның минерал-җитештерү комплекслары бәяләнә, ТРның һәм аңа чиктәш терр-яләрнең минераль-чимал базасы торышы һәм үсеше перспективалары картасы төзелә. ТРның «Җир асты байлыклары турында» канунын эшләүдә катнаша. Дәүләт бүләге Татарстан Респ-касында төзелеш материалларының минераль-җитештерү комплексын үстерү проблемаларын геол. һәм икътисади тикшергәне һәм нигезләгәне өчен бирелә. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Карта состояния и перспектив развития минерально-сырьевой базы промышленности строительных материалов Республики Татарстан. Екатеринбург, 1992 (автордаш); Методическое руководство по поискам, оценке и разведке месторождений твёрдых нерудных полезных ископаемых Республики Татарстан: В 3 ч. К., 1999–2001 (автордаш).

**САДЫ́ЙКОВ** Ревдар Фәез улы (20.1.1937, БАССРның Мишкә р-ны Мишкә а. — 21.11.1989, Казан), балет артисты, педагог, ТАССРның халык (1964), РСФСРның атказ. (1970) артисты. 1955 елда Ташкент хореография уч-щесен (педагоглары — Е.Новиков, З.Афанасьев) тәмамлый. 1955–56 да — Үзбәкстан, соңыннан Саратов опера һәм балет театрларында балет артисты. 1956–77 дә Татар опера һәм балет театры балет солисты, 1977–80 дә педагог-репетиторы. С. виртуоз биюче, барлык бию алымнарының катлаулы арсеналы б-н иркен эш итә белә. Исккиткеч



Р.Ф.Садыйков.

артистлык талантына ия. С.ның биюенә чиста, төгәл башкару манерасы, җиңеллек, тизлек, әчке хисләргә байлык хас. Аның актёрлык диапазоны бик киң: лирик-романтик рольләрдән алып героик-романтик, гротесклы-классик һәм драматик хореографик партияләргә кадәр. С. татар балетында ирләр биюе техникасын нык күтәрә, шактый гына биюле образларны башкаруның тарихи нигезләрен салып калдыра. Хореографик партияләре арасында — Альберт («Жизель», А.Адан), Зигфрид, Дезире («Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл», П.Чайковский), Базиль («Дон Кихот», Л.Минкус), Ленин («Яшен сукмагы», К.Караев), Шүрәле, Былтыр («Шүрәле», Ф.Яруллин), Гайфи, Алмай («Су анасы», Ә.Бакиров), Клим («Тау әкияте», А.Ключарёв), Гали («Раушан», З.Хәбибуллин). ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1973).

*Әд.:* М е л ь н и к о в Г. Так становятся артистами // Театральная жизнь. 1960. № 5; Л у ц к а я Е. Ревдар Садыков // Советская музыка. 1964. № 5; Народные артисты. К., 1980.

*В.Н.Горшков.*



Р.Ф.С а д ы й к о в Былтыр ролендә («Шүрәле» балеты, Ф.З.Яруллин; Шүрәле — С.З.Хәйруллин, Сөембикә – С.Х.Хантимерова).

**САДЫ́ЙКОВ** Ренат Әхәт улы (12.5.1952, Казан), җылылык энергетигы, техник фән. д-ры (1989), проф. (1990). 1975 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1983 тә Казан ун-тын тәмамлый. 1989 дан Түбән Кама химия-технол. ин-ты директоры һәм технол. процессларны автоматлаштыру каф. мөдире (1990 нан). 1993 тән «Түбәнкаманефтехимэкспорт» пр-тиесенең директор урынбасары, «Түбәнкаманефтехим» АҖнең Болгариядәге вәкиллеге (София) директоры. 2001–04 тә Казан энергетика ун-тында, 2005 тән Казан архит-ра-төзелеш ун-тының җылылык энергетикасы каф. мөдире. Хезмәтләре төрле продукт һәм материалларны киптерү процесслары һәм аппаратларына, матем. модельләштерүгә һәм технол. процессларын оптимальләштерүгә карый. С. күп компонентлы сыек фазасы аерып алынган җылыга чыдамсыз продуктларны вакуумда киптерү теориясен эшли. Химик һәм микробиологик синтез нәтиҗәсендә табылган термолабиль һәм төерләнүчән продуктларны киптерү өчен аппаратлар һәм җайланмалар эшли. Җылылык һәм масса күчерүнең иярешле мәсьәләләрен чишү алымнарын, җылылык һәм материаль агымнарны вакланмалы дифференцирлау кулланып исәпләү методикасын, чикләүче конструкцияләрнең дымлылык режимын һаваны фильтрлауны исәпкә алып билгеләү ысулларын тәкъдим итә. Энергия саклау һәм җылылык энергетикасы мәсьәләләренә караган хезмәтләр авторы. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Процессы переноса при кратковременном контакте фаз. К., 2004; Энергосберегающие технологии сушки биоактивных продуктов. К., 2006 (автордаш); Dehydration of Biological origin. New Hampshire, USA, 2004 (автордаш).

**САДЫ́ЙКОВ** Фәнис Гыйльман улы (1.2.1936, БАССРның Әлшәй р-ны Нигъмәтулла а.), хирург, мед. фән. д-ры (1990), проф. (1990). БАССРның атказ. табибе (1986). Башкорт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), Яңавыл район хастаханәсендә эшли. 1966 елдан санитария авиациясе хирургы. 1968 дән БАССРның Респ-ка клиник хастаханәсендә балалар хирургиясе бүлеге мөдире. 1970 тән Башкорт мед. ин-тында, 1990 нан балалар хирургиясе каф. мөдире. Хезмәтләре балаларда калкансыман биз аутоиммун авыруларына диагноз куюга карый. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Эпидемический зоб у детей и подростков в Башкирской АССР. Уфа, 1973; Клиническая патофизиология детского возраста. СПб., 1997 (автордаш).

**САДЫ́ЙКОВ** Фәһим Ибнеәмин улы (16.6.1928, БАССРның Мәсәгут кантоны Яңа Мөслим а. — 23.6.1998, Башкортстан Респ-касы Уфа ш.), философ, филос. фән. д-ры (1973), Башкортстан Респ-касы ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1977). Свердловск пед. ин-тының тарих ф-тын тәмамлый (1950). 1950–53 елларда СССР ФАнең Урал ф-лында (Свердловск ш.), 1956–62 дә Чиләбе политехник ин-тында. 1962 дән Новосибирск ун-тында, 1966 дан Ставрополь а.х. ин-тында, филос. каф. мөдире. 1969 дан Башкорт ун-тында, проф. (1976 дан), филос. каф. мөдире (1978–90). Хезмәтләре социаль философиягә, социологиягә, политологиягә, әхлакка карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Коммунистическая нравственность. Новосиб., 1963; Единство народа и противоречия социализма. Ставрополь, 1968; Особенность советской цивилизации. Уфа, 1998.

**САДЫ́ЙКОВ** Хәким Садыйк улы (22.10.1916, Пермь өлкәсенең Уинск р-ны Түбән Сып а. — 29.12.2009, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (18.4.1944, 28.6.1944, 24.3.1945), гв. старшинасы. Туган авылында колхозда эшли. 1941 елның июненнән Кызыл Армия сафларында. 1941 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 26 нчы аерым гв. разведка ротасы разведчигы (22 нче һәм 3 нче удар армияләрнең 21 нче гв. укчы дивизиясе). Калинин һәм 2 нче Балтыйк буе фронтлары гаскәрләре составында Калинин оборона операциясендә (1941), Ржев-Вязьма (1943), Рига (1944) һәм Варшава-Познань (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1945 нең 17 апрель төнендә каршы Опочка шәһәреннән (Псков өлкәсе) 50 *км* көнчыгыштарак разведка операциясендә батырлык күрсәтә: разведка төркеме б-н дошман тылына бәреп керә; автомат уты һәм граната белән траншеядагы солдатларны юк итәләр һәм дивизия штабына «тел» алып кайталар; 1944 нең 1 июненә каршы төндә Мелехово торак пункты (Эргли шәһәреннән 10 *км* көньяктарак, Латвия) янындагы разведка операциясендә: разведчиклар төркеме б-н мина кырын, чәнечкеле киртәләрне үтеп чыга; дошманның 5 солдатын юк итәләр, берсен әсир алалар; 1944



Х.С. Садыйков.

нең 3 июлендә Воробьи торак пункты (Полоцк шәһәреннән төньяктарак) янындагы разведка операциясендә: разведчиклар төркеме б-н засадада граната б-н 2 мотоциклчыны шартлата, «тел» алып бәйли, бергәләп аны үзләренең сугышчылары урнашкан урынга алып кайталар. 1945 тә демобилизацияләнгәннән соң, туган авылында яши, колхозда эшли. 1 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**САДЫ́ЙКОВ** Эдгар Камил улы (1.1.1942, Әлки р-ны Яңа Салман а.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1994), проф. (1995), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1964 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, каты җисем физикасы каф. мөдире (1992–2007). Хезмәтләре каты җисемнәрне гамма-резонанслы тикшерүгә карый. С. магнитлы материалларның радиоешлыклы кырларга тәэсир итү үзлекләрен тыштан контрольдә тоту шартларында мёссбауэр нурланышының резонанслы флюоресценциясе теориясен, икеле гамма-электрон-магнит резонансы теориясен эшли. Мёссбауэр күчешләрендә квант интерференциясе эффектларын тикшерә. Таралган мёссбауэр нурланышы көченең таралуның сыгылма һәм сыгылма булмаган (раманча) каналлары арасында тотрыклы бүленешен ачыклый.

Х е з м.: Мёссбауэровские спектры р. ч. модулированных магнитных стохастических бистабильных систем // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1990. Т. 52, № 2 (автордаш); Квантовая интерференция в спектрах мёссбауэровского рассеяния // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 2005. Т. 82, № 7 (автордаш); Определение вероятности безотдачного поглощения гамма-квантовоядрами в твердых телах методом задержанных совпадений // Уч. зап. Казан. ун-та. Сер. Физ.-матем. науки. 2010. Т. 152. № 1 (автордаш); The theory of double Gamma Resonance in paramagnetics // Phys. Stat. Solidi (b). 1984. V. 123.

**САДЫ́ЙКОВА** Аида Гомәр кызы (12.4.1952, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (2002), проф. (2004). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1975), Яшел Үзән р-ның Васильево посёлогында укытучы булып эшли. 1978 елдан Татар гуманитар-пед. ун-тында, 2002 дән контрастив лингвистика һәм тәрҗемә каф. мөдире, 2006 дан чит телләр ф-ты деканы. 2011 дән Казан ун-тында: рус һәм чит телләр бүлегендә герман филол. каф. профессоры. Хезмәтләре төрки һәм герман телләренең лексик системаларын чагыштырма тикшерүгә карый.

Х е з м.: Новые исследования в зарубежной лингвистике. К., 2004; Когнитивно-коммуникативное исследование фразеологической окказиональности. К., 2009.

**САДЫ́ЙКОВА** Айсылу Хөсәен кызы (27.4.1946, Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь р-ны Уразавыл а.), фольклорчы, әдәбият белгече, филол. фән. д-ры (2002), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Горький өлкәсенең Кучкай Пожары авылы мәктәбендә эшли. 1970 елдан Казанда яши. 1972–77 дә ТАССР Үзәк дәүләт архивында фәнни хезмәткәр. 1977 дән ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында, баш фәнни хезмәткәр (2004 тән). Татар әдәбияты һәм фольклорының үзара бәйләнешен, татар халык иҗатына ислам диненең тәэсирен өйрәнә. «Бәетләр» (2000), «Мөнәҗәтләр» (2000, рус теленә тәрҗемәсе «Мунаджаты», 2005), «Татар халык иҗаты: Әкиятләр» (1–2 т., 2008) җыентыкларының автор һәм мөхәррирләреннән берсе; «Татар халык иҗаты: Әкиятләр» («Татарское народное творчество: Сказки», т. 3, 2008), «Татар халык иҗаты: Табышмаклар» («Татарское народное творчество: Загадки», т. 4, 2008) җыентыкларын рус теленә тәрҗемә итә.

Х е з м.: Ислам һәм татар халык иҗаты. К., 2005; XII — XX гасыр башы татар әдәбиятында дини фольклор. К., 2014; Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова. К., 1995; Идеология ислама и татарское народное творчество. К., 2001.

**САДЫ́ЙКОВА** Зәйнәп Садыйк кызы (9.1.1921, Зөя кантоны Олы Шырдан а. — 22.6.1977, Яшел Үзән ш.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, Соц. Хезмәт Герое (1966). Олы Шырдан тулы булмаган урта мәктәбен тәмамлаганнан соң (1936), Яшел Үзән р-нында эшли: Куйбышев исем. к-зда хисапчы, Олы Шырдан авыл советы секретаре (1937 елдан), рәисе (1938 дән), Олы Шырдан сельпо рәисе (1939 дан), Куйбышев исем. к-з рәисе (1941 дән); район милиция бүлеге уполномоченные (1943 тән), уполномоченный ярдәмчесе (1945), өлкән уполномоченный (1947 дән); Вахитов исем. к-з рәисе (1955 тән), «Нурлат» с-зы директоры (1967 дән). С. җитәкче булганда, Вахитов исем. к-зда сыерлар һәм бозаулар өчен 5 бина, яшелчә саклау урыны, клуб төзелә, җитештерү объектлары һәм торак йортлар электрлаштырыла. Еллык акча кереме 103,3 меңнән 415 мең сумга арта. 1955–65 тә сыер һәм дуңгызларның баш саны, ит җитештерү 2 тапкыр, сөт 870 *ц* дан 5300 *ц* га кадәр арта. Сату планы 1965 елда 182% ка үтәлә. Соц. Хезмәт Герое исеме җитештерүдәге тотрыклы югары күрсәткечләр өчен бирелә. 1959–63 тә ТАССР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**САДЫ́ЙКОВА** Зидә Рәшит кызы (10.4.1935, БАССРның Салават р-ны Нәсибаш а.), тел галиме, филол. фән. канд. (1986). Казан ун-тын тәмамлый (1960). 1960–2008 елларда ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында эшли. Хезмәтләре татар теле диалектологиясе, лексикологиясе һәм тарихына карый. *«Урта Идел һәм Урал буе татар халкы сөйләшләре атласы»*н, «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»н (2009) һ.б. татар диалектологик сүзлекләрен төзүчеләрнең берсе.

Х е з м.: Говоры оренбургских татар. К., 1985; Зоонимическая лексика татарского языка. К., 1994; Названия хозяйственных построек и инвентаря в татарском языке. К., 2003.



З.С. Садыйкова.



Л.М. Садыйкова.

**САДЫ́ЙКОВА** Ләлә Махиян кызы (25.1.1928, Бөгелмә кантоны Татар Кандызы а. — 5.7.1995, Әлмәт ш.), драма актрисасы, ТАССРның халык артисты (1978). Сәхнә эшчәнлеген 1943 елда БАССРның Туймазы посёлогы мәдәният йорты агитбригадасында башлап җибәрә; 1944 тән — Туймазы татар күчмә, аннары Буа колхоз-совхоз театрлары актрисасы. 1955 тән Әлмәт татар драма театры труппасында. Ялкынлы, дәртле актриса буларак, С. әлеге театр сәхнәсендә, тирән психологизм б-н сугарылган зур масштаблы образлар иҗат итеп, истә калырлык шактый рольләр башкара: Фирүзә («Соңгы очрашу», С.Кальметов), Тәнзилә («Тальян моңы», Ш.Бикчурин), Фәридә



Л.М. С а д ы й к о в а Поля ролендә («Васса Железнова», М.Горький).

(«Кандыр буе», К.Тинчурин), Айсылу («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Җир-ана («Анам кыры», Ч.Айтматов), Бостанбубый («Әниләрем — бәгырь кисәкләрем», А.Каххар), Ак түти, Әнисә («Көзге ачы җилләрдә», «Кар астында кайнар чишмә», А.Гыйләҗев), Канакай («Кузы Көрпәш һәм Баянсылу», Г.Мөсрәпов), Шәхсәнәм («Иске йорт кешеләре», Р.Хәмид) һ.б. С.ның ирекле, ныкихтыяр көченә ия, дәртле, гайрәтле героинялары эчке һәм тышкы матурлыклары ягыннан кабатланмас, колоритлы булулары б-н аерылып торалар. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**САДЫ́ЙКОВА** Разия Габделәхәт кызы (23.1.1959, Куйбышев р-ны Әҗмәр а.), педиатр, мед. фән. д-ры (2005), ТРның атказ. табибе (1999). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1982), Биектау үзәк район хастаханәсендә эшли. 1990 елдан ТР МК Аппаратының сәламәтлек саклау буенча баш референты. 1997 дән «Татарстанфармация» дәүләт унитар пр-тиесе ген. директоры. 2000 нән ТР МК каршындагы Респ-ка халык арасында наркотизация профилактикасы үзәге директоры. 2004 тән ТР МК Аппаратының наркотикларга каршы эшчәнлекне координацияләү бүлеге башлыгы. Хезмәтләре җәмгыяви сәламәтлек өлкәсенә карый, фәнни тикшеренүләре наркоманияне кисәтүгә, ТРда наркотикларга каршы алып барылучы эшчәнлекнең төп юнәлешләрен билгеләүгә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Общество против наркотиков: Информация, технология, опыт. К., 2002 (автордаш); Стратегия и основные направления антинаркотической работы в РТ // Наркозависимость и медико-социальные последствия: стратегии профилактики и терапии. К., 2003.

**САДЫ́ЙКОВА** Сара Гариф кызы (1.11.1906, ачыкланган мәгълүматлар буенча 1903, Казан — 7.6.1986, шунда ук), җырчы (лирик-колоратуралы сопрано), актриса, композитор, ТАССРның халык артисты (1977), РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1984). Композиторлар берлеге әгъзасы (1982). 1921 елда Казан пед. техникумында уку дәверендә беренче тапкыр К.Рәхимнең «Бүз егет» пьесасы буенча куелган хәйрия спектаклендә Сәхибҗамал ролендә актриса һәм җырчы буларак уңышлы чыгыш ясый. Композитор С.*Габәши* тәкъдиме б-н Мәскәүгә укырга китә, 1922–28 дә Мәскәү консерваториясе каршындагы музыка техникумында вокал буенча М.Г.Цыбущенко классында укый. 1920 елларда Мәскәү үзәк татар эшче театры сәхнәсендә драма актрисасы буларак чыгышлар ясый. 1930–34 тә Татар акад. театрында эшли, муз. драма спектакльләрендә, ш.и. К.Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар», «Зәңгәр шәл», «Кандыр буе», Т.Гыйззәтнең «Наёмщик» муз. драмалары буенча куелган спектакльләрдә төп рольләрне башкаручы буларак



С.Г. Садыйкова. 1986.



С.Г. Садыйкова.

таныла. 1934–38 дә Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә укый. 1938–48 дә Татар опера һәм балет театры солисты, татар композиторларының опера һәм муз. комедияләрендә төп партияләрне (Рәйхана, Саҗидә — «Качкын», «Илдар», Н.Җиһанов; Галиябану — шул исем. әсәр буенча, М.Мозаффаров; Сәрвәр — «Башмагым», Җ.Фәйзи) уңышлы башкара. Концерт бирүче җырчы буларак зур популярлык казана. Йомшак, чиста, җиңел, төрле төсмерләргә бай матур тавышка ия. Башкару манерасы эчке хисне ача белүе, эчкерсезлеге, сөйкемлелеге б-н аерылып тора. Актёрлык талантына җыр-моңга сәләте дә өстәлә. Татар вокал сәнгате тарихында беренчеләрдән булып, ул милли репертуарга аерым бизәкләр кертә башлый. Җырчының концерт репертуарына, башлыча, татар һәм башкорт халык көйләре, татар композиторларының җырлары, романс һәм арияләр керә. Татарстанның проф. җыр сәнгате үсешенә зур өлеш кертә.



С.Г. С а д ы й к о в а Сания ролендә («Сания», Г.С. Әлмөхәммәдов, В.И. Виноградов, С.Х. Габәши).

С.ның иҗаты, композитор буларак, барыннан да бигрәк җыр жанры б-н бәйле. Ул — моңлы, матур тавышлы җырчы; татар муз. фольклорының иң яхшы традицияләре тарафдары. С.ның җырлары берничә дистә еллар дәвамында гаять популяр булып, күбесе халык җырларына әверелә. Ул, гадәти интонацияләргә, халыкчан җыр, марш һәм бию көйләре ритмнарына игътибар итеп, аларны татар халык музыкасы стиле б-н табигый рәвештә берләштерә (татар композиторларыннан беренче булып танго һәм фокстрот жанрларына мөрәҗәгать итә). С. җырларының тематикасы киң. Аның иң яхшы лирик җырлары — халык традицияләрен һәм С.Сәйдәшев, З.Хәбибуллин, М.Мозаффаров һ.б.ның җыр мирасын дәвам итүче җырлар. Аеруча популяр җырлары – Ә.Ерикәй шигыренә «Көтәм сине», М.Ногман шигырьләренә «Оныта алмасам нишләрмен», «Балкый Шәйморза утлары», Г.Бәширов шигыренә «Җидегән чишмә», Х.Туфан шигыренә «Казан кичләре» һ.б.

С. актив мәдәни һәм иҗтимагый эшчәнлек алып бара. Казанда М.Горький исем. клуб каршында халык хорын оештыра һәм күп еллар дәвамында аны җитәкли. Талантлы яшьләрне музыка сәнгатенә җәлеп итә. Күпләгән милли композиторлык һәм башкару сәнгате вәкилләренең иҗади үсешенә йогынты ясый. Татар халык җырларын җыя.


ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1990, вафатыннан соң). С. истәлегенә һәм аның мирасын пропагандалауга балалар һәм яшьләр музыка конкурслары һәм фестивальләре, Казанда, Мәскәүдә, С.-Петербург һ.б. шәһәрләрдә концертлар, телевизион фильмнар багышлана. Казанда мемориаль такта куела, Чаллыда концерт залына С. исеме бирелә. 1992 дән Апас р-ның Тутай авылында *Садыйкова Сара музее* һәм 1996 дан Казанда Сара Садыйкова фонды эшли.

Төп әсәрләре: Р.Гобәйдуллин б-н автордашлыкта «Мәхәббәт җыры» (1971) һәм «Кияүләр» (1972) муз. комедияләре, спектакльләргә музыка; 300 дән артык җыр, инструменталь әсәрләр һ.б.

*Әд.:* Н у р л ы г а я н о в Я. Моң чишмәсе // Казан утлары. 1973. № 2; З ә й н а ш е в а Г. Сара Садыйкова. К., 1987; Сагыналар сине якын дуслар: С.Садыйкова турында истәлекләр. К., 1991; А й д а р с к а я А.Г. Память сердца. К., 2002; ш у л у к. Рәхмәт җыры — Песнь благодарности. К., 2005; ш у л у к. Путешествие в мир чарующей мелодии // Казань. 2006. № 10–11.

*Ф.Ш.Салитова.*

**САДЫ́ЙКОВА САРА́ МУЗЕ́Е**, Апас р-ның Тутай авылында. 1992 елда С.*Садыйкованың* әнисенең туган ягында ТР Дәүләт музее (2001 дән ТР Милли музее) ф-лы буларак ачыла; 2007 дән муниципаль музей. Махсус төзелгән бинада урнаштырылган. Экспозиция мәйданы — 75,6 *м*². Фондта 1 меңнән артык саклау берәмлеге. Экспозиция С.Садыйкованың тормышы һәм иҗат эшчәнлегенә багышлана, аның шәхси әйберләре: (кызы Ә.Г.Айдарская тарафыннан тапшырылган) чүлпылары, концерт күлмәкләре, гастрольләргә йөргән чемоданы, патефоны, С.Садыйкованың үз язмалары һәм танылган шагыйрьләрнең шигырьләренә иҗат иткән көйләре язылган 1930 еллар пластинкалары, 1960 ның ахыры — 1980 елларда язылган инструменталь әсәрләре, спектакльләргә язылган музыка б-н аудиокассеталар. Музей экспонатлары арасында 1930 да Мәскәүдә С.Садыйко-



Сара Садыйкова музее. Экспозиция фрагменты: концерт күлмәге һәм башка шәхси әйберләре.

ва сатып алган фарфор ваза, 1939 да Ташкент шәһәрендә җырчыга бүләк итеп бирелгән үзбәк келәме, композиторның Петербург рәссамы Фәйзрахман Камалов эшләгән портреты (2006) бар.

Ел саен Музей ачылган көн (10 июнь), Җиңү көне (9 май), Халыкара музейлар көне (18 май), С.Садыйкова туган көн (1 нояб.) үткәрелә.

**САДЫ́ЙКОВА** Тамара Илдус кызы (8.2.1967, Баулы р-ны Бәйрәкә а.), педиатр, мед. фән. д-ры (2007). Казан мед. ин-тын тәмамлый(1987). 1991 елдан Казан мед. академиясендә эшли (бүленеп, 1993–2000 дә ТРның Аналар һәм балалар сәламәтлеген саклау үзәгендә), җәмгыяви сәламәтлек, икътисад һәм сәламәтлек саклау өлкәсе идарәсе каф. профессоры (2008 дән), каф. мөдире (2012 дән). Фәнни тикшеренүләре ТР мисалында үсмер кыз балалар сәламәтлеге мәсьәләләренә, амбулатор-поликлиника ярдәме күрсәтүнең торышы, тенденцияләре, бу өлкәдә оптимальләштерү юлларын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Социальный фактор в формировании здоровья российского подростка // Общественное здоровье и здравоохранение. 2005. № 3–4 (автордаш).

**САДЫЙКЫ́Й-ҖАЕКЫ́Й** Габдулла Гыйззәт угылы (19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөзнең 1 нче чиреге), язучы. Тәхәллүсенә караганда, чыгышы б-н Җаек шәһәреннән яки аның якын-тирәсеннән булса кирәк. Ливандагы Америка колледжында белем ала. Уку чорында «Бөек бер сәрвәт, яхуд Бик зур бер байлык» (1898) романын һәм «Хыялдагы тереклек, яки Зарлану һәм моңлану» (1899) хикәясен яза. Хикәясенең кереш сүзендә «Тарих әл-әнбия» (ихтимал, Н.Рабгузиның «*Кыйссас әл-әнбия*» әсәренең татарчага тәрҗемәсе) әсәрен язуын әйтеп үтә. Галим М.В.Гайнетдинов мәгълүматларына караганда 1920–30 елларда Г.Сөләймани тәхәллүсе б-н бернечә дәреслек һәм уку-укыту әсбабы бастырып чыгара.

**САЕСКА́Н** (Pica pica), каргалар семьялыгындагы кош. Евразиядә, Америка һәм Африканың төньяк-көнбатышында таралган. Татарстан терр-ясендә утрак һәм өлешчә күчмә төр. Агач һәм куаклар үскән биотопларда яши. С. шәһәр һәм авыл торак пунктларына оялый. Гәүдәсенең озынлыгы — 45–48 *см*, авырлыгы — 160–260 *г*. Каурый капламы яшькелт металлсыман ялтыравыклы кара; түше һәм корсагы, сырт һәм канатларындагы киң сызыклар ак төстә. Койрыгы озын, киртләч-киртләч. С. ботакта утырган килеш еш кына кисәк чәрелдәп дерелди һәм койрыгы б-н тирбәнә. Оясын (яннан керү юлы булган ябык, шарсыман формада) агачларда кора. Көрән тимгелле 5–9 яшькелт йомырка сала. Җәен бөҗәкләр, көзен җиләк-җимеш, яшелчә б-н, кышын чүплекләрдә һәм терлек каралтылары янында туклана. Кош ояларын туздырып һәм йомыркаларын, ш.у. кош балаларын ашап, зарар китерә.

**САЕСКА́Н ТАВЫ́** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 23 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 60 кеше (руслар, татарлар) яши. Клуб. 1646 дан мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, алебастр чыгару һәм эшкәртү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.Т.нда земство мәктәбе (1876 да ачыла), тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 852 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Масловка волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 118 ир-ат; 1859 да — 543, 1897 дә — 870, 1908 дә — 1156, 1920 дә — 1093, 1926 да — 660, 1949 да — 314, 1958 дә — 297, 1970 тә — 269, 1989 да — 133, 2002 дә — 74 кеше.

С.Т. авылы янында Кама елгасы аша салынган автомобиль күпере бар.

**САЕСКА́Н ТАВЫ́ ШӘҺӘРЛЕГЕ́**, археол. истәлек; Балык Бистәсе р-ны Саескан Тавы авылы янындагы Ананьино культурасы торулыгы (якынча б.э.к. 8–4 йөзләр).1879 елда П.А.Пономарёв тарафыннан ачыла. С.т.ш. истәлекләре 1880–82, 1885 тә П.А.Пономарёв (1881 дә А.А.Штукенберг б-н берлектә), 1909 да А.М.Тальгрен, 1982 дә В.Н.Марков, 1990–91 дә А.Х.Халиков, 2007 дә А.А.Чижевский һ.б. тарафыннан тикшерелә. С.Т.ш.нең мәйданы 73×72 *м*. Кырга тоташкан яктан шәһәрлек «кокошник» рәвешендәге ур (нигезе киңлеге 8,5 тән 11 *м* га, биеклеге 1,3 *м*, чокыр төбеннән 3 *м*, сырт озынлыгы буенча якынча 74 *м*) һәм дугалы чокыр (киңлеге 6–8 *м*, тирәнлеге 1–1,7 *м*) б-н аерыла. Шәһәрлек мәйданының зур булмаган төньяк-көнбатыш өлеше (18×18 *м*) һәм аңа тоташкан урның 20 *м* озынлыктагы өлеше сакланып калган. Озак елларга сузылган тикшеренүләр нәтиҗәсендә С.Т.ш.ндә Ананьино культурасына нисбәтле тораклар табыла, чокырлы-шнурсыман бизәкләр төшерелгән шактый зур керамика коллекциясе, таштан, сөяктән, мөгездән, чакматаштан, бронзадан һәм тимердән эшләнгән күпсанлы әйберләр туплана.

*Әд.:* П о н о м а р ё в П.А. Предварительное сообщение о результатах раскопок в Лаишевском уезде близ с. Шурана и д. Сорочьи Горы, произведённых летом 1881-го года действительным членом П.А.Пономарёвым // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1884. Т. 3; Археологическая карта Татарской АССР. Предкамье. М., 1981; М а р к о в В.Н. Керамика городища Сорочьи Горы // Археологические памятники Нижнего Прикамья. К., 1984; Б у г р о в Д.Г., Р у д е н к о К.А., Х а л и к о в А.Х. Укрепления Сорочьегорского городища // Памятники древней истории Волго-Камья. К., 1994.

*А.А.Чижевский.*

**САЕСКА́Н-ШӨЛДИ́** (Haematopus ostralegus), шөлди кошлар семьялыгындагы кош. Гәүдә озынлыгы якынча 40 *см*, авырлыгы 500 *г* га кадәр. Өстендә, баш һәм буксәсендә каурый капламы кара, аскы ягы ак төстә. Томшыгы озын, туры, ян-яктан кысылган, сары-кызыл төстә. Канатлары очлы. Койрыгы кыска, туры кисемле. Аяклары кыска, кызыл. Евразия һәм Африкада таралган. 19–20 йөз башында Татарстан терр-ясендә шөлдиләрнең гадәти оя коручы төре була. Комсу сайлыклар сусаклагыч сулары астында калганнан һәм кече һәм уртача елгаларның яр буйлары кеше тарафыннан үзләштерелгәннән соң, аларның саны кискен кими. Идел, Кама һәм аларның кушылдыклары үзәнендә яши. Күчмә кош. Апрель уртасыннан сентябрьгә кадәр очрый. Яхшы оча, йөгерә һәм йөзә. Зур һәм кечкенә утрауларга, ш.у. күлләрнең саз үләннәре үскән баткаклы ярларына оялыйлар. Оясы — кабырчык һәм вак ташлар түшәлгән ачык чокырчык. Кара-коңгырт тимгелле 3–4 аксыл-сары йомырка сала. Балалары июнь башында чыга. Моллюсклар, бөҗәкләр һәм аларның личинкалары, суалчаннар, кысласыманнар б-н туклана. ТРның Кызыл китабына кертелгән.



В.А.Сажинов.

**САЖИ́НОВ** Виктор Александрович (1.2.1925, Казан — 23.4.1945, Берлин), Сов. Союзы Герое (15.4.1945), гв. рядовое. Заводта токарь булып эшли. 1943 елда үз теләге б-н фронтка китә. 1943 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 53 нче гв. танк бригадасының идарә ротасы разведчигы (3 нче гв. танк армиясенең 6 нчы гв. танк корпусы). Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Киев һөҗүм һәм оборона операцияләрендә (1943), Житомир–Бердичев (1943–44) һәм Висла–Одер (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Радомско шәһәре (Польша) читендә Нид елгасын кичеп чыкканда разведка операциясендә батырлык күрсәтә: 1945 нең 14–16 гыйнварында беренчеләрдән булып кичүгә бәреп керә һәм танкларга елга аша чыгу юлын күрсәтә; разведчиклар төркеме б-н дошманга каршы сугышып, укчы подразделениесенә алга баруны тәэмин итә; күп тапкырлар разведкага бара һәм аннан кыйммәтле мәгълүматлар алып кайта. Берлин шәһәре янындагы сугышта командирның гомерен саклап С. һәлак була. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*


**САЗ ЙОЛДЫЗЫ́**, с у й о л д ы з ы (Callitriche), саз үләннәре семьялыгыннан күбесенчә берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 25 тән артык төре билгеле. ТР терр-ясендә 3 төре: үзгәрүчән С.й. (C. polymorpha), ике җенесле С.й. (C. hermaphroditica), гади С.й. (C. palustris) бар. Сазлыкларда, кечкенә култык, инеш, буа һәм күлләрдә очрыйлар, куак-

лыклар хасил итәләр. 3–50 *см* биеклектәге үсемлекләр, тулысы б-н суга күмелгәннәр яки су өслегендә йөзәләр. Яфраклары ачык яшел, каршыдаш, яфрак таралгысында урнашканнар. Йөзүче яфрак таралгылары күп нурлы матур йолдызчыкны хәтерләтә. Чәчәкләре вак, 1–2 шәр яфрак куентыгында урнашкан, су өстенә чыгып торалар. Җимеше — дүрт чикләвекчек. Майдан көзгә кадәр чәчәк ата. С.й. куаклыгы вак умырткасызлар өчен качу урыны, балыклар азыгы һәм шунлыктан балык хуҗалыгында әһәмияте зур.

**САЗ МИРТЫ́**, саз куагы (Chamaedaphne Moench), арчанчалар семьялыгыннан мәңге яшел куакчыл үсемлекләр ыругы. 100 гә якын төре билгеле — Европада, Азиядә, Америкада таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — гади С.м. (Ch. calyculata Moench) үсә. Яшел Үзән, Биектау, Кукмара һәм Минзәлә р-ннары терр-ясендә очрый. Торфлы сазлыкларда, йөзмә «үлән-утрауларда» үсә. 30–100 *см* биеклектәге үсемлек, кыска тамырчалы һәм чук тамыр системалы. Сабагы — соргылт-көрән төстә. Яфраклары ланцетсыман, калын, өске ягы куе яшел, асты күгәрек төсендә. Чәчәкләре вак, аксыл, бүрәнкәле кыңгыраусыман, иенке, бер яклы яфраксыз чукларда. Майда чәчәк ата. Җимеше — тартмачык. Декоратив, баллы, дару үсемлеге (яфракларыннан ясалган төнәтмә көзәнгә каршы чара буларак кулланыла). Сарык һәм кәҗәләр өчен агулы үсемлек.

**САЗ РУДАСЫ́**, к. *Лимонит.*

**САЗ ТАШБАКАСЫ́** (Emys orbicularis), төче су ташбакалары семьялыгыннан сөйрәлүче. Евразиядә, Төньяк-көнбатыш Африкада таралган. Татарстан терр-ясендә Олы һәм Кече Чирмешән елгалары бассейнында (Нурлат һәм Әлки р-ннары) очрый. Күл, сазлык һәм акрын агымлы елгаларда яши. Гәүдәсе кабарынкы арка (карапакс) һәм яссы корсак



Саз ташбакасы.

(пластрон) калканыннан торучы панцирь б-н капланган. Панцирьның нигезен 23 *см* га кадәр озынлыктагы озынча түгәрәк формадагы тиречел сөяк тәшкил итә; төсе караңгы зәйтүнсыманнан коңгырт көрәнгә кадәр, аның фонында вак сары нокталар, таплар һәм сызыклар сибелгән. Койрыгы озын. Аяклары, башы һәм койрыгы кара, аларга саргылт (сирәк кенә алсу) бизәкләр сибелгән. Тәпиләрендә йөзү элпәләре бар. С.т. күбесенчә иртән һәм эңгер-меңгердә актив. Яхшы йөзә һәм чума, су астында озакка калырга мөмкин. Октябрьдә кышкы йокыга тала, апрель–майда уяна. Сулыклар төбендә кышлый. Парлашу суда да, коры җирдә дә бара. Арткы аяклары б-н казыган чокырга ана зат 3–10 йомырка сала. Инкубация чоры 70–100 тәүлек. Җенси яктан яшәвенең 6–8 елында җитлегә. Бөҗәкләр, кысласыманнар, моллюсклар, бакалар, ш.у. суүсемнәр б-н туклана. С.т.ның ояларын еш кына төлке, кама, каргалар туздыра. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Г а р а н и н В.И., Е г о р о в И.Я., Р я б о в а Г.А. Животный мир Восточного Закамья (позвоночные). Альметьевск, 2000.

**САЗА́Н** (Cyprinus carpio), карплар семьялыгыннан. Евразиянең төче сулыкларында яши. Татарстан терр-ясендә Идел, Кама, Вятка, Ык һ.б. елгаларда, ш.у. буа һәм күлләрдә таралган. Озынлыгы 1 *м* га, авырлыгы 16 *кг* га җитә, гәүдәсе алтынсу төстәге циклоидасыман тыгыз эре тәңкә б-н капланган. Сырт йөзгече озын, аз гына уемтылы, сырт һәм койрык асты йөзгечләрендә берәр тешле сөяк нурлар бар. Авыз кырыйлары һәм өске иреннәре пар мыеклы. Җенси җитлегү чоры — яшәвенең 2–5 елында. Ябышкак уылдыгын май ахыры – июньдә, су темп-расы 17 °С һәм югарырак булганда, йомшак суүсемнәргә өлешләп чәчә. Үрчемлелеге — 800 меңгә кадәр уылдык бөртеге. Яшь балыклар — зоопланктон, зурлары бентос, үсемлекләр һәм бөҗәк личинкалары б-н туклана. С. — җылылык яратучы балык. Тирән чокырларда кышлый. Кәсәбәчелек һәм үрчетү өчен кыйммәтле балык. Селекция юлы б-н С.ның культуралы формасы — карп чыгарыла. Илл. *Балыклар* мәкаләсендә.

**САЗАНА́К**, багульник, чабыр куагы, үрмә рәйхан (Ledum), арчанчалар семьялыгыннан мәңге яшел куакчыл үсемлекләр ыругы. 10 га якын төре билгеле, Төньяк ярымшарның салкын һәм уртача поясларында таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — саз чабыр куагы (L. palustre) бар. Төньяк-көнбатыш районнарда торфлы сазлыкларда үсә. 50–100 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы ятма, күтәрелеп торучы күп санлы ботаклы. Яшь үрентеләре куе җирән-коңгырт төкчәле, карт ботакларның кабыгы шома, соры-коңгырт төстә. Яфраклары чиратлашкан, кыяк, кыска сабаклы, калын, аска таба төрелгән читле, асты җирән киезсыман. Чәчәкләре ак, сирәк кенә — кызгылт, чатырсыман чукка җыйналган. Җимеше — озынча, биш оялы, күп орлыклы тартмачык. Июньдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыктан һәм тамыр үсентесеннән үрчи. Баш әйләндергеч гаять көчле исле (саз чабыр куагының халык биргән «саз миңгерәткече» исеме шуннан) үсемлек. Җир өсте өлешләрендә эфир мае, яфракларында гликозид һәм дуплау матдәләре бар. Дару үсемлеге: медицинада чәчәкле ботаклары һәм яфраклары — какырык чыгару чарасы. Яфраклары бөҗәкләргә каршы кулланыла.



Саз чабыр куагы.

**САЗЛЫ́К**, коры җирнең артык дымланган урыны, анда таркалмаган органик матдәләр, нигездә, үсемлекләр *торфка* әйләнә. Минераль туфраклы яки торф утырмасы 0,3 *м* га кадәр булган С.лар — сазлыклы җирләр, 0,3 *м* дан артык булса, торфлы С.лар дип йөртелә.

ТР терр-ясендә 2 меңгә якын аерым С. исәпләнә, ш.у. 5 мең С. 1 меңгә кадәр С. массивлары барлыкка китерә. Гомумән, алар ТР терр-ясенең 0,4% ын (28 мең *га*) били. Нигездә, С.лар зур түгел, аларның яртысының диярлек мәйданы 1 *га* дан артмый. Зур С.лар — 16 (мәйданнары 100 *га* һәм күбрәк), нигездә, Идел, Зөя, Кече һәм Олы Чирмешән, Ашыт, Мишә, Ык елгалары үзәннәрендә. Респ-каның иң зур сазлыклары: *Көлгеш сазлыгы* (4900 *га*), *Татар Әхмәте торфлы сазлыгы* (805 *га*), Октябрина сазлыгы (507 *га*).

С.ны беренче тикшеренүләр 19 йөзнең 2 нче яртысында ботаниклар (Р.А.Кокс, С.И.Коржинский, П.Н.Крылов, Н.П.Потапьевский һ.б.) тарафыннан үткәрелә. Үсемлекләр алмашы тарихын өйрәнгәндә, Казан геоботаника галимнәре (С.И.Коржинский, А.Я.Гордягин һ.б.) С. катламнарын тикшерә. С. флорасын беренче максатчан юнәлешле тикшеренүләрне 1910 елда В.И.Баранов, И.Г.Бейлин башлый. ТАССР ХКС 1943 тә респ-каның урман-дала районнарындагы (Куйбышев, Кузнечиха, Бөгелмә) С.ларын тикшерүне оештыра. С.ларны комплексны тикшерүләр — ТРның Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, бот. һәм геоморфологик тикшеренүләр — Казан ун-ты, геол. тикшеренүләр — ЦНИИгеолнеруд., тар тематикалылар а.х. һ.б. оешмалар тарафыннан үткәрелә.

Респ-ка терр-ясендәге С.ның күпчелеге элеккеге күл һәм елга юлларында барлыкка килгән. Агымсыз яки әкрен агымлы сулыкларның үсемлекләр б-н каплануы — үзәктән читтәге сай сулы участоклардагы үсемлекләрнең тамырланып сулыкның үзәк өлешенә якынаюы һәм үсүе — суда йөзүче һәм, гадәттә, яр б-н бәйле үсемлек капламы (йөзмә «үлән-утрау») сулыкларның сазлыкланууына китерә. Еш кына ике күренеш тә бер үк вакытта күзәтелә. Сулыкларның сазлыклануына кеше эшчәнлеге дә йогынты ясый. ТРда сусаклагычлар төзелгәннән соң, аларның яр буе зоналарында С.лар барлыкка килү процессы көчәя. Урманнарны кисү һәм терр-яне сукалау эрозия процессларының көчәюенә китерә, һәм шул сәбәпле респ-каның күп кенә сулыклары ләмләнә һәм сазлана. Сәнәгать һәм а.х. үсеше б-н сулыкларда азот, фосфор, калий һ.б. матдә кушылмалары туплана башлый, алар исә сазлык үсемлекләре үсешенә уңай йогынты ясый. Терр-янең сусаклагыч сулары астында калуы, урманнарны кисү, сазлыкларны киптерү һәм торф чыгару б-н кире процесс — сазлыкларның деградациясе һәм юкка чыгуы күзәтелә.

Татарстанда С.лар геоморфологик торышы буенча 4 төркемгә бүленә: тугай, терраса, сөзәклек һәм субүләр С.лары. Елга тугайларында С. барлыкка килүгә җир өсте сулары ташкыны режимы, язгы ташу, ш.у. грунт сулары чыгу булыша. Тугайларның сазлыклануы уртача 2,8–3,7% тәшкил итә; Агыйдел,




1. Куйбышев сусаклагычындагы сазлыклы сай сулык; 2. Чишмә елгасы үзәне сөзәклегендәге сазлык.

Зөя, Ык, Олы һәм Кече Чирмешән, Ашыт һәм Мишә елга үзәннәренең кайбер участокларында С.лар тугай мәйданының 10–15% ын алып тора һәм күп очракта зур массивлар хасил итә. Күп кенә тугай С.лары, сусаклагычлар төзелгәннән соң, су астында кала, аларның гомуми мәйданы — 11 мең *га*, аеруча зурлары Идел елгасы террасаларында (мәйданы 1,4 мең *га*). Терраса С.ының яртысыннан артыгы (56%) уртача зурлыктагы елга үзәннәрендә. Әлеге геоморфологик төркемгә Көләгеш сазлыгы керә, ул Кама, Агыйдел һәм Ык елгаларының тугай өсте террасаларында урнашкан. Терраса С.лары респ-ка терр-ясендә 14 мең *га* мәйдан били. Сөзәклек С.лары тау битләренең авыш участокларында таралу алган, аларның барлыкка килүенә су горизонтлары чыгышы һәм җир өсте сулары агышы тәэсир итә. Күп кенә сөзәклек С.лары Көнчыгыш Кама аръягында, аеруча төньяк-көнчыгышта — Бәҗәнә, Бижады, Шәбез һәм районның үзәк өлешендә — Зәй–Ык елгалары арасындагы үзәндә, ш.у. Идел алдында — Зөя, Алгама, Гөбенә, Карлы, Үләмә, Таллык елгалары үзәннәрендә. Сөзәклек С.ларының яртысыннан артыгы (54%) борынгы (плейстоцен) сызаларның төпләренә туры килә, алар сөзәклек өслекләрен катлауландыра. Сөзәклек С.лары 2,5 мең *га* мәйдан били. Субүләр С.лар йомык түбәнлекләрдә һәм килеп чыгышы төрле булган казанлыкларда барлыкка килә. Алар өчен мөһим шарт — су басымлы горизонт булу, төп туену чыганагы — атм. явым-төшемнәре һәм җир өсте сулары агышы. Респ-ка терр-ясендә әлеге типтагы С.лар ара-тирә Көнчыгыш Кама аръягында (үзәк өлештә һәм төньяк-көнчыгышта) очрый. Субүләр С.лар якынча 500 *га* мәйдан били.

Үсемлекләр дөньясы һәм туену режимы буенча уйсу, арадаш һәм үрге С.ларга аерып йөртәләр. ТРда уйсу типтагы (эвтроф) С.лар өстенлек итә, грунт һәм елга сулары б-н туена; минераль матдәләргә бай туенуга корылган үсемлек бергәлекләре үсә. Респ-каның көнбатыш чигендә ара-тирә үрге С.лар (олиготроф) очрый, аларда, нигездә, минераль туенуга талымсыз үсемлекләр үсә. Арадаш С. (мезотроф), нигездә, аз санда Идел террасасында очрый, уйсу һәм үрге С.лар арасында арадаш халәтне били.

ТРдагы С.лар флорасы: үләнчел үсемлекләрдән — күрән, гади курак, күл камышы, тар яфраклы һәм киң яфраклы җикәнбаш, болын үсемлекләре вәкилләре һ.б.; агач-куаклардан — каен, зирек, тал, кайвакыт чыршы, нарат һ.б.; мүкле торф (үрге һәм арадаш С.лар) һәм гипнум мүкләр (уйсу типтагы кайбер С.лар).

С. фаунасы: ондатра, су тычканнары, буа бакасы, көрән бака, гади тузбаш, соры торна, соры каз, чуллык, зур шөлди, кыр үрдәге, сыбызгы чүрәкәй, соры челән, камыш чыпчыгы, бурсык чыпчык. С.лар ш.у. күчмә кошлар (каз, үрдәк, шөлди һ.б.) өчен тукталу урыны. Респ-ка икътисады өчен кызыксыну тудыралар (торф һәм сапропель чыганаклары). Кайбер С. утырмалары бальнеологик әһәмияткә ия (к. *Шифалы ләмнәр*).

*Әд.:* Кац Н.Я. Болота и торфяники. М., 1941; Баранов В.И. Болота и торфяники Татарии. К., 1947; шул ук. Кулигаш // Тр. КФ АН СССР. Сер. биол. и с.-х. наук. 1948. Вып. 1; Арискина Н.П. Экскурсия на торфяное болото. К., 1961; Горшков Ю.А., Аюпов А.С. Ресурсы водоплавающих птиц Татарии. К., 1989; Апкин Р.Н. Закономерности распространения болот на территории Республики Татарстан. К., 2002.

*Р.Н.Апкин.*

**САЗО́НОВ** Николай Дмитриевич (5.5.1858 — 19.11.1913, С.-Петербург; Мәскәүдә җирләнә), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, статский советник (1905). Дворяннар катлавыннан, эре җир биләүче (Казан губ., Спас өязе Кызыл Бистә авылы янында 2,5 мең дис. нәсел утары була), токымлы атлар үрчетүче. 1812 елгы Ватан сугышы герое, генерал-майор Ф.В.Сазонов оныгы, Россиянең тышкы эшләр министры С.Д.Сазоновның абыйсы. С. танылган мари галиме һәм җәмәгать эшлеклесе М.Н.Сазоновның (Янтимер) исем атасы була, бала чагында аны үз гаиләсенә алып тәрбияли. Түбән Новгород хәрби гимназиясен тәмамлый, атлы полк лейб-гвардиясендә хезмәт итә. 1880–85 тә Тамбов губернаторы канцеляриясендә. 1883 тә Спас өязенең земство җыены С.ны губерна гласные итеп, 1884 тә Спас өязенең шәрәфле җәмәгать судьясы итеп сайлый. 1897 дән Спас өязе дворяннары башлыгы. 1898 дән Казан губернасы дворяннары башлыгы (1905 тә, авыру сәбәпле, 3 нче тапкыр сайланудан баш тарта) һәм Казан губернасының земство җыены рәисе. 1904 нең сентябрь аенда Казан губернасында, Идел һәм Кама буе пристаньнарында хәрәкәттәге армия өчен фураж ашлыгы сатып алу буенча баш вәкил итеп билгеләнә. 1904 нең декабрендә Император сарае гофмейстеры итеп билгеләнә. 1907 дә гомуми эшләр департаменты буенча Эчке эшләр министрлыгына беркетелә. 1908 нең сентябрь аенда өстәмә сайлауларда Казан губернасыннан Дәүләт Думасы әгъзасы итеп сайлана. Төрле вакытта урталыктагы уң партия, рус милләтчеләре һәм бәйсез милләтчеләр фракцияләренә керә; эшчеләр мәсьәләсе, мөрәҗәгатьләр, дәүләт оборонасы буенча комиссияләр әгъзасы. Аграр реформа, оборона, чиркәү тормышы, токымлы атлар үрчетүгә ярдәм итү, террорчылык актлары, провокаторлар эшчәнлеге һ.б. мәсьәләләр буенча чыгышлар ясый. Хөкүмәтнең рев-ция б-н көрәш сәясәтен, империя милләтчелеге нигезендә әҗнәбиләр б-н якынаю идеясен яклый. Бернично тапкыр уң караштан торып кадет һәм социалистлар б-н бәхәсләшә. Казан губернасында «рус милләтчеләре» сәяси лагерен оештыруда катнаша. Казандагы рус сайлау ком-тында (1911 нең декабреннән) һәм Казандагы рус милли клубының җитәкче советында тора (1912 нең башыннан). Җирле «милләтче» оешмалар эшчәнлегенә һәм аларның 4 нче Дәүләт Думасына сайлаулар буенча алып барган кампаниясенә яшерен рәвештә юнәлеш бирә. Казан губернасының земство хастаханәсе попечителе (1900 дән), Кызыл Хач җәмгыятенең Казан идарәсе әгъзасы (1900 дән), Мария Александровна карамагындагы Император сукырларга җәмәгать тәрбиясенең Казан бүлекчәсе советы вице-рәисе (1903 тән). Казан губернасында 1899 елгы ачлык вакытында ачыгучыларга ярдәм оештыруда катнаша. 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Алексеев И.Е. Под сенью царского манифеста (умеренно-монархические организации Казанской губернии в начале ХХ века). К., 2002; Усманова Д.М. Депутаты от Казанской губернии в Государственной думе России. 1906–1917. К., 2006.

*И.Е.Алексеев.*

**САЗТАМА́К** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 10 *км* көнбатыштарак, Норма елгасы буенда. 2010 елда 300 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1719 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Деревня по речке Нурме, Пустошь по речке Нурме исемнәре б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, ярма яргыч, 2 вак-төяләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 809,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 34 ир-ат; 1859 да — 418, 1897 дә — 482, 1908 дә — 660, 1920 дә — 539, 1926 да — 467, 1938 дә — 401, 1949 да — 361, 1958 дә — 445, 1970 тә — 454, 1979 да — 372, 1989 да — 264, 2002 дә — 298 кеше.

**САЗТАМА́К** тимер юл разъезды посёлогы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 10 *км* көн-

батыштарак, Казан–Екатеринбург тимер юл станциясе буенда. 2010 елда 16 кеше (татарлар) яши. 1940 елларда нигез салына. Оештырылган көненнән — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Кукмара р-нында. Халык саны: 1989 да — 16, 2002 дә — 18 кеше.

**САИ́ТОВ** (Сәетов) Олег Элекпаевич (26.5.1974, Куйбышев өлкәсенең Новокуйбышевск ш.), спортчы (бокс), Россиянең атказ. спорт остасы (1995). Казан ун-тының журналистика һәм социология ф-тын тәмамлый (2006). Спорт б-н 1980 еллар ахырында шөгыльләнә башлый, тренерлары — К.Логинов, И.П.Уткин. 1990 нан Куйбышев өлкәсенең Жигулёвск шәһәрендә яши. Европа, дөнья (1992, яшүсмерләр арасында), БДБ (1993), Россия (1996, 2000), дөнья (1997), Европа (1998, 2004) чемпионатларында, Олимпия уеннарында (1996, 2000, 67 *кг* авырлык категориясендә) җиңүче; СССР беренчелегендә (1988, көмеш), дөнья чемпионатларында (1993, бронза; 1995, көмеш), Россия (1994–95, көмеш), Европа (1996, бронза), Игелекле уеннар (1994, бронза), Олимпия уеннарында (2004, бронза) медальләр ала. Вел Бейкер Кубогы (2000), Россия Олимпия ком-тының «Фейр Плей» призы иясе (1998, гадел уен). 2005–2009 дан Самара өлкәсенең Физик культура һәм спорт департаменты җитәкчесе. 2009–2012 дә Самара өлкәсенең спорт, туризм һәм яшьләр сәясәте министры урынбасары, 2012–13 тә Самара өлкәсенең спорт министры вазифаларын башкара, 2013–15 тә министр. Жигулёвск шәһәренең Мактаулы гражданы (1996). 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», Дуслык орденнары б-н бүләкләнә.

**САЙГА́НОВ** Абдулла Җамалетдин улы (18.5.1913, Әстерхан ш. — 19.4.1974, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1972). Әстерхан пед ин-тын тәмамлый (1940). 1943 елдан Казанда, ТАССРның Мәгариф халык комис-ты инспекторы. 1946 дан Казан. пед. ин-тында, 1953 тән татар әдәбияты кафедрасын җитәкли, бер үк вакытта, 1948–54 елларда, тарих-филол. ф-ты деканы. Эзләнүләре реализм эстетикасына, татар реалистик әдәбиятында типиклык мәсьәләсенә, татар һәм рус әдәбиятлары бәйләнешләренә, шигырь төзелешенә карый. Хезмәтләре Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Ш.Камал, Һ.Такташ, Г.Кутуй иҗатларына багышлана. Урта мәктәпләр өчен татар әдәбияты дәреслекләре һәм хрестоматияләр авторлашы. Бөек Ватан сугышында катнаша.

Ә с ә р.: Проблема типического в татарской реалистической литературе. К., 1972; У истоков эстетики реализма: Эстетика Фатиха Амирхана и её место в развитии татарской реалистической литературы. К., 1982.

**СА́ЙКИН** Семён Фёдорович (14.9.1914, Казан губ., Буа өязе Чепкас-Ильметьево а. — 10.9.2002, Чабаксар ш.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1965), проф. (1968), Чуаш. АССРның атказ. фән эшлеклесе (1975), Чуаш Респ-касы ФАнең шәрәфле әгъзасы (1994), Чуаш Респ-касы Милли фән һәм сәнгать академиясенең шәрәфле әгъзасы (1994). 1937 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1941 дә Чкаловск пед. ин-тының теоретик механика кафедрасында, 1944 тән Казан суворовчылар хәрби уч-щесендә. 1951 дән Казан ун-тында: Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында, җир асты гидромеханикасы бүлеге мөдире (1952 дән), физика-матем. (1958–61) һәм механика-матем. (1961–67) ф-тлары деканы. И.Н.Ульянов исем. Чуаш ун-тының беренче ректоры (1967–81, Чабаксар ш.), бер үк вакытта теоретик механика каф. мөдире (1967–87), шул ук кафедраның профессоры (1987 дән). Хезмәтләре аналитик механикага, механиканың вариативлык принципларына, җир асты гидромеханикасына карый. С. су-нефть контакты формалашу һәм аның хәрәкәте мәсьәләләрен тикшерә. Бериш булмаган һәм аерым кисәкләре бериш булмаган нефть катламнарында басым кырын билгеләү алымы авторларының берсе. СССР ЮС (1970–79), Чуаш АССР ЮС (1981–85) депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. С. исеме Чуаш АССРның Хезмәт даны һәм батырлыгы мактау китабына кертелгән.

Х е з м.: О дифференциальных принципах механики // Уч. зап. Казан ун-та. 1952. Т. 112, кн. 9; Водонефтяной контакт и некоторые гидромеханические методы определения его положения. К., 1964; Дифференциальные принципы механики // Изв. АН Чуваш. Респ. 1994. № 2 (автордаш).

**САЙЛА́У СИСТЕ́МАСЫ**, сайлаулар оештыру һәм уздыру, тавыш бирү нәтиҗәләрен ачыклау тәртибе. Сайлау округларының «бүлемен», сайлаучылар исемлекләрен төзүне, сайлау органнарын оештыруны һ.б.ны рәсмиләштерә. 1917 елда хәзерге Татарстан терр-ясендә совет С.с. гамәлгә кертелә. РСФСРның 1918 елгы Конституциясе буенча сайлау хокукы, нинди расадан, милләттән, кайсы җенестән булуына, нинди дин тотуга карамастан, 18 яше тулган барлык хезмәт ияләренә бирелә. Сайлау хокукыннан табыш алу максатында яллы хезмәттән файдаланган, хезмәттән тыш керем хисабына яшәгән затлар, хосусый сәүдә б-н шөгыльләнүчеләр һәм арадашчылар, руханилар, элеккеге жандармерия, полиция һәм сак бүлекчәсе хезмәткәрләре мәхрүм ителә. Советлар съездларында эшчеләр сыйныфы вәкилләренең крәстияннәргә карата биш тапкыр өстенлекләрәк дәрәҗәсе гамәлдә була. С.с. шәһәр һәм авыл советларына турыдан-туры сайлауны күздә тота. Барлык югары сайлаулы хакимият органнары советлар һәм советлар съездлары тарафыннан делегатлар сайлау юлы б-н формалаша. Шәһәр советларына сайлауларда — пр-тиеләрдә, авыл советларына сайлауларда авылларда ачык тавыш бирелә. Сайлаулардагы барлык чикләүләр һәм өстенлекләр СССРның — 1936 елгы, ТАССРның 1937 елгы Конституцияләре кабул ителгәннән соң бетерелә. СССРның 18 яшькә җиткән барлык гражданнары советларга депутатлар сайлауда катнашуга хокуклы була. Түбәннән югарыга кадәрге хакимият органнары гомуми, тигез, турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш биреп сайлана. Бу принциплар ТАССРның 1978 елгы Конституциясендә дә саклана. Татарстанда С.с. үсешендә ТРның 1992 елгы Конституциясе кабул ителү яңа адым була. Конституциядә ТР Президентын, ТР ЮСына (1995 тән Дәүләт Советы) һәм халык депутатларының җирле советларына сайлаулар дәүләт хакимиятенең әлеге органнары вәкаләтләре тәмамлануга 4 ай калудан да соңармыйча билгеләнә дип раслана. ТРда С.с.ның төп принциплары — яшерен тавыш бирү юлы б-н гомуми, тигез һәм турыдан-туры сайлау. 18 яшькә җиткән гражданнар сайлау хокукына ия; кандидатлар сайлаучыларның эш, уку, хезмәт, яшәү урыннарындагы гомуми җыелышларында, ш.у. партияләр һәм иҗтимагый оешмалар тарафыннан күрсәтелә; сайлаулар альтернатив нигездә уздырыла; сайлауларны әзерләү һәм уздыру б-н бәйле чыгымнарны дәүләт үз өстенә ала; гражданнар өчен кандидатларны ирекле һәм һәрьяклап тикшерү мөмкинлеге, җыелышларда, массакүләм мәгълүмат чараларында агитацияләү хокукы гарантияләнә. Сайлаулар сайлау округлары буенча оештырыла, аларны уздыру ТР Үзәк сайлау комиссиясенә буйсынулы сайлау комиссияләре тарафыннан тәэмин ителә.

Чыг.: Татарстан Республикасы Конституциясе (Төп Законы). К., 1993; Татарстан Республикасы Конституциясе (Төп Законы). К., 2002; Конституция (Основной Закон) Российской Советской Федеративной Социалистической Республики. М., 1918; Конституция (Основной Закон) Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. К., 1937; Конституция (Основной Закон) Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. К., 1978; Конституция (Основной Закон) Республики Татарстан. К., 1992.

*Е.Б.Долгов.*

**САЙРРАНИЛА́Р**, Шәркый Төркестанның җәмәгать эшлеклеләре, мәгърифәтчеләре. 1) **Хәйдәр Сайррани** (1886–1943), Шөнҗанда (Көнбатыш Кытай) С. династиясен нигезләүче, баштарак Уфада, 1905–09 елларда Казанда яши. 1909 дан Өремче шәһәре уку йортларында укыта. Татар һәм уйгыр мәктәпләре өчен җәдитчә уку әсбаплары һәм программалары авторы. Өремчедә уйгыр телендә заманча вакытлы матбугат оештыручыларның берсе. Шәркый Төркестан халыкларының милли азатлык хәрәкәтендә катнаша. 1938 дә гоминьданчылар тарафыннан кулга алына, соңрак җәзалап үтерелә; 2) **Уйгыр Хәйдәр улы** (1919), галим, җәмәгать эшлеклесе, публицист. 1950–60 елларда «Шөнҗан газетасы»ның җаваплы мөхәррире, Өремчедә Академия үзәген оештыручы; 3) **Рөстәм Хәйдәр улы** (1927–44), Шәркый Төркестан халыкларының милли азатлык хәрәкәтендә катнашучы, гоминьданчылар тарафыннан җәзалап үтерелә; 4) **Урхан Хәйдәр улы** (1932–68), химик, Пекин пед. ин-тында укыта; 5) **Ирек Хәйдәр улы** (1935), табиб, профессор, Шөнҗан мед. ун-тында баш уролог; 6) **Илче Хәйдәр улы** (1939), метрология белгече, проф. 1999 дан Өремчедә Татар мәдәнияте җәмгыятен җитәкли.

**САКА́ЕВ** Нури (Нуретдин) Нәбиулла улы (1.7.1885, Уфа губ., Бәләбәй өязе Шланлы-

күл а. — 3.3.1927, Казан), драма актёры, режиссёр, татар проф. театрының беренче актёрларыннан берсе. Бәләбәйдәге башлангыч мәктәптә һәм Оренбург шәһәрендәге «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. И.Кудашев-Ашказарскийның туганы буларак, 1907 елда аның труппасына керә, труппаның халык алдындагы тәүге чыгышларында актив катнаша. 1908 дә Г.Кариев труппасына күчә (Уральск ш.), анда 1912 гә кадәр эшли. 1912–15 тә — «Нур», 1915 тән «Ширкәт» труппасында. 1921 дән Казанда Беренче татар дәүләт драма театры труппасында; 1922–25 тә Уфа шәһәрендә башкорт театры һәм күчмә башкорт труппасы режиссёры. 1926 да Казанга Татар акад. театрына кайта. Нигездә, характерлы һәм комик рольләр башкара: Васька («Бәхетсез егет», Г.Камал), Габделхаликъ («Помада мәсьәләсе», И.Богданов), Саттар («Ямьсез тормыш», Ф.Сәйфи-Казанлы), Сафый бай («Тигезсезләр», Ф.Әмирхан), Тимерхан, Нуретдин («Беренче чәчәкләр», «Җилкәнсезләр», К.Тинчурин), Осип, Ляпкин-Тяпкин («Ревизор», Н.В.Гоголь) һ.б. Хезмәт Герое (1926).

*Әд.:* Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; Татар театры (1906–1926). К., 2003; Иллялова И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала: Биоблиогр. белешмәлек. К., 2005.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**САКÁЕВА** Мәстүрә Фәхретдин кызы (15.1.1916, Уфа губ., Бәләбәй өязе Табанлыкүл а. — 16.5.2007, Уфа ш.), нефролог, БАССРның атказ. табибе (1966), Соц. Хезмәт Герое (1969). Башкорт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1941), 1741 нче һәм 5913 нче эвакогоспитальләрдә эшли. 1947–90 елларда Респ-ка клиник хастаханәсендә (Уфа), 1958–84 тә урология бүлеге мөдире. Уронефрология профиленә караган авыруларга махсус мед. ярдәме күрсәтү ысулларын тәкъдим итә. Аның җитәкчелегендә Башкортстанда беренче тапкыр гемодиализ ясала. Респ-ка клиник хастаханәсендә ясалма бөер бүлеге булдырыла. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Павлов В.Н., Коржавин Г.В. Урологии Башкортстана 60 лет. Уфа, 2008.

*Г.У.Аллабирдина.*

**САКЛÁУ** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 66 *км* көньяктарак, Чушкан елгасы буенда. 2010 елда 1 кеше (татар) яши. 19 йөзнең 2 нче яртысында җирбиләүче морза Измаил-бәк Чыңгыз (Чыңгызов) утары буларак нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Зәетов Пүчинкәсе, Зәетов утары, Чушкан исемнәре б-н дә билгеле. 1905 елларда С. тирәсендәге җирләрне 2 нче гильдия сәүдәгәр А.З.Зәетов сатып ала һәм Минзәлә өязенең Югары Саклау авылы крәстияннәрен шунда яшәргә чакыра. Зәетов иганәсенә мәктәп (1910) һәм таш мәчет (1911; архит-ра истәлеге) төзелә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Салауш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1897 дә — 34, 1915 тә — 200, 1926 да — 188, 1938 дә — 198, 1949 да — 163, 1958 дә — 135, 1970 тә — 57, 1989 да — 9, 2002 дә — 4 кеше.

*Әд.:* Мәрданов Р.Ф. Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**САКЛАУБÁШ** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Саклаусу елгасы буенда. 2010 елда 528 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөз уртасына кадәр нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.та мәчет, мәктәп, 7 кибет була; шимбә базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 6072,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Нөркәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Сарман р-нында. Халык саны: 1795 тә — 287, 1859 да — 538, 1870 тә — 1128, 1897 дә — 1589, 1920 дә — 1795, 1926 да — 1267, 1938 дә — 960, 1949 да — 629, 1958 дә — 462, 1970 тә — 615, 1979 да — 570, 1989 да — 546, 2002 дә — 573 кеше.

**САКЛАУСÝ** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Минзәлә елгасының (Кама елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 15 *км*, бассейнының мәйданы 114,7 $км^2$. Сарман р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Саклаубаш авылыннан 4 *км* көньяктарак, тамагы Чураш авылыннан көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы — 88 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. С.ның 0,8 дән 10,3 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар, иң зурысы — Катусат (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,55 $км/км^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 73 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,01 $м^3/с$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. С. бассейнында суының гомуми күләме 3,5 млн. $м^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**САКМÁР РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* үзәгендә урнашкан. 1935 елда оештырыла. Мәйданы — 2061 $км^2$. Үзәге — Сакмар авылы (Оренбургтан 36 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 29334 кеше (2013). Татарлар саны: 1970 тә — 4485, 1979 да — 4642, 1989 да — 5081, 2002 дә — 5766, 2010 да — 5922 кеше. Районга 3 татар авылы — Үрге Чебенле һәм Түбәнге Чебенле, Татар Каргалысы (Каргалы бистәсе) керә. С.р. терр-ясендә татарларның килеп чыгуы Россиянең Урта Азия һәм Шәрекъ илләре б-н сәүдә бәйләнешләренең җайга салынуы б-н бәйле. 1744 тә 200 гә якын татар гаиләсе Казан губернасыннан Оренбург губернасына күчерелә, монда алар *Каргалы бистәсен* нигезли (хәзер Татар Каргалысы а.). 1754 тә бу авылдан күченүчеләр Үрге Чебенле һәм Түбәнге Чебенле авылларын нигезли. Каргалы бистәсе озак еллар Россия татарларының зур сәүдә-икътисад, мәгърифәт һәм мәдәният үзәге булып кала. 20 йөз башында 10 мәчет эшли, совет власте чорында аларның күбесе җимерелә. 1976 да диндарларга «Кушманара» мәчете (1795 тә төзелә) кире кайтарыла. Хәзерге вакытта Татар Каргалысында 3 мәчет, «Нур» мәдрәсәсе эшли, ислам мәгърифәт комплексы бинасына нигез салына, айга 1 тапкыр «Оренбург манарасы» дини-агарту г-тасы нәшер ителә. 1995 тән мөселман җәмгыяте, Татар Каргалысы урта мәктәбе һәм С.р. җитәкчеләре б-н берлектә җәйге мөселман балалар лагере оештырыла. Татар Каргалысы һәм Үрге Чебенле мәктәпләрендә татар теле фән буларак укытыла, татар мәдәниятенә багышланган музейлар эшли. Шагыйрьләр Ә.*Каргалый*, Г.*Утыз Имәни*, сәүдәгәр *Хөсәеновларның*, Сов. Союзы Герое Х.Ш.*Фәйзуллинның* тормышы С.р. б-н бәйле.

**СÁКОН** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 9 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 66 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Чуерташ з-ды. 1646 дан Кодыбирде авылы буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Архангельский исеме б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу, штукатурлау, йөн эрләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Михаил-Архангел чиркәве (1700 дә төзелгән иске чиркәү урынына 1864–65 тә салына; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе (беренчесе — 1849 да, кабат 1884 тә ачыла), җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1781 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Алексеев волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1921–22 дә Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 306 ир-ат; 1859 да — 977, 1897 дә — 847, 1908 дә — 959, 1920 дә — 1134, 1926 да — 1139, 1938 дә — 935, 1949 да — 652, 1958 дә — 531, 1970 тә — 353, 1979 да — 259, 1989 да — 154, 2002 дә — 113 кеше.

*Әд.:* Алексеевский район: История и современность. К., 2000.

**САКСИ́Н** (Сасция, Саксония, Суммеркент), Түбән Иделдәге (Идел елгасы тамагындагы) урта гасырлар (11–13 йөзләр) шәһәре. Шәрекъ (әл-Гарнати, әл-Казвини һ.б.) һәм Көнбатыш Европа (Юлиан, Дж. де Плано Карпини, В.Рубрук) авторлары хезмәтләрендә телгә алына. Идел буе Болгарының сәяси йогынтысында була. С.да 1130–50 елларда яшә-

гән әл-Гарнати: «Шәһәр үзәгендә Болгар халкы әмире яши, аларның биш вакыт намаз укыла торган җамигъ мәчетләре бар, һәм аның тирәсендә болгарлар яши», — дип яза. С.ның сан буенча икенче урында торган халкы — гузлар. 1229 да монголлар болгарларга, кыпчакларга һәм Саксинның Идел аръягында яшәүчеләренә һөҗүм итә, соңрак шәһәрне камалышка ала. 1236 да шәһәр җимертелә. «С.» атамасы көнчыгыш һәм тарихи-геогр. традицияләрдә Түбән Идел буе төбәге атамасы буларак яши. Шәһәрнең археол. калдыклары Әстерхан өлкәсендәге Самосдельский шәһәрлеге урыны б-н бәйләп карала.

Чыг.: Путешествия в Восточные страны Плано Карпини и Рубрука. М., 1957; Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг.). М., 1971.

*Әд.:* Ф ё д о р о в - Д а в ы д о в Г.А. Город и область Саксин в XII–XIV вв. // Древности Восточной Европы. М., 1969; В а с и л ь е в Д.В. О болгарском компоненте населения Самосдельского городища в дельте Волги // Древность и средневековье Волго-Камья: Материалы Третьих Халиковских чтений. К.–Болгар, 2004; И з м а й л о в И.Л. Защитники «Стены Искандера». К., 2008. *И.Л.Измайлов.*

**САК-СОК**, бәет. Жанрның иң борынгы үрнәкләреннән берсе. Ике игезәк сабыйны әнкәләренең каргавы, шуннан аларның, Сак б-н Сокка (фантастик кошлар) әверелеп, гомер буе әти-әнисе һәм бер-берсе б-н кавыша алмый яшәүләре бәян ителә. Ана каргышы нәтиҗәләре темасы фольклорда еш чагыла. Балаларның кошларга әверелү архаик сюжеты дөнья халыклары авыз иҗаты әсәрләрендә еш очрый. Татар халкының шигъри иҗатында Сак б-н Сок мәңгегә аерылышу символларына әверелә. Татарстан, Башкорстанның күпчелек районнарында һәм ТРдан читтә татарлар күпләп яшәгән башка терр-яләрдә бәетнең төп 2 версиясе яши. Кульъязмалар ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының фольклор фондында саклана. Бәет 20 йөз башында нәшер ителә. Материалларны туплау һәм бәетне өйрәнү б-н Х.Ш.Мәхмүтов, Л.Ш.Җамалетдинов, Ф.В.Әхмәтова, И.Н.Надыйров һ.б. шөгыльләнә.

*Әд.:* У р м а н ч е е в Ф. Сак-Сок бәетләре // Татар халык иҗаты: Бәетләр. К., 1983; Сак-Сок // Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987. *Ф.И.Урманчеев.*

**САЛ КҮЛЕ́**, Көнчыгыш Кама алдында. Вятка елгасы туганының сулъяк яр буенда, Кукмара р-ны шәһәр тибындагы Лубян посёлогыннан 4 *км* төньяк-көнбатыштарак һәм Плаксиха авылыннан 1 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы 9,76 *га*. Озынлыгы 1160 *м*, иң зур киңлеге 250 *м*. Сузынкы, катлаулы формада. Яр буе өлешендә урыны-урыны б-н саз үсемлекләре үсә.

**САЛ КҮЛЕ́**, Идел алдында. Идел елгасының уңъяк төп ярында, Яшел Үзән р-ны Улитино авылыннан 1,8 *км* көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы 0,12 *га*. Су күләме 6 мең *м*$^3$. Озынлыгы 50 *м*, киңлеге 30 *м*, уртача тирәнлеге 5 *м*, иң зур тирәнлеге 9 *м*. Күл карст процесслары нәтиҗәсендә хасил булган. Озынча түгәрәк формада. Ярлары текә, күтәренке. Туенуы җир асты сулары исәбенә, тотрыклы. Суы йомшак (2,5 *мг-экв/л*), җиңелчә минеральләшкән (60,1 *мг/л*), чиста (үтә күренмәлелеге 500 *см* га кадәр), гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта. Хуҗалык-көнкүреш һәм ял итү максатларында файдаланыла. ТРның табигать истәлеге (1978).

**САЛА́ КӨШКӘ́Т** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 12 *км* төньяктарак, Көшкәт елгасы буенда. 2010 елда 184 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау, игенчелек. Клуб. 18 йөз башына кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Киселёво исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, киез итек-киез басу, чыпта сугу б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 669,8 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Чепья волостенда, 1921 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1746 да — 42, 1763 тә — 62, 1795 тә — 91, 1811 дә — 177 ир-ат; 1850 дә — 165, 1859 да — 195, 1884 тә — 159, 1897 дә — 199, 1905 тә — 210, 1910 да — 240, 1920 дә — 291, 1926 да — 277, 1938 дә — 317, 1949 да — 254, 1958 дә — 199, 1970 тә — 196, 1979 да — 201, 1989 да — 162, 2002 дә — 192 кеше.

**САЛАБА́ЕВ** Альберт Михайлович (1.8.1941, Чуаш АССРның Канаш ш.), хокук белгече, РФнең атказ. юристы (1998). Казан ун-тын тәмамлый (1970). 1965–70 елларда ТАССР Финанс министрлыгында өлкән инспектор. 1970–73 тә Казанның Идел буе р-ны халык мәхкәмәсе халык судьясы. 1973–82 дә ТАССР ЮС әгъзасы. 1982–87 дә КПССның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы. 1987–2004 тә ТР юстиция министры. 2004–07 дә Социаль белем бирү академиясенең (Казан) юридик ф-ты деканы, 2008 дән гражданлык хокукы каф. мөдире. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**САЛАВА́Т** шәһәре, Башкортстан Респ-касының көньягында, Уфадан 160 *км* ераклыкта урнашкан. 1948 елда посёлок буларак нигезләнә, 1954 тә шәһәр статусын ала. Халкы — 154593 кеше (2008). Татарлар саны: 1970 тә — 19794, 1979 да — 28351, 1989 да — 30212, 2002 дә — 32214, 2010 да — 32351 кеше. «Агыйдел» мәдәният-ял үзәге каршында «Сандугач» татар халык эстрада-фольклор ансамбле эшли. Татар телендә «Салават таңы» г-тасы нәшер ителә. 2004/05 уку елында шәһәрнең 10 мәктәбендә укыту татар телендә бара. Сов. Союзы герое Х.Б.*Әхтәмовның* тормышы С.ш. б-н бәйле.

**«САЛАВА́Т КҮПЕРЕ́»**, балалар өчен айлык рәсемле журнал. 1990 елның мартыннан Казанда татар телендә нәшер ителә. «ТАТМЕДИА» АҖ ф-лы. Оештыручысы — ТРның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы. Нашире — «С.к.» ж-лы редакциясе. Баш мөхәррирләре — З.З.Хөснетдинов (1990–2012), З.З.Хөснетдинова (2012 дән). Мәктәп балаларына тәгаенләнә. Язмалар балаларга эстетик һәм әхлакый тәрбия бирүгә, аларда туган телгә, татар әдәбиятына, сәнгатенә, милли гореф-гадәтләргә мәхәббәт уятуга юнәлдерелә. «Әлифба дәресе», «Яшь рәссам», «Иҗатчы», «Сак бул!», «Оста куллар», «Булдырам!», «Гөлбакча», «Әкияттерапия», «Тәрбияче биштәре» һ.б. даими сәхифәләр чыгып килә. Журналның Шүркә, Елмай, Йомшаккай, Матуркай, Шалай кебек үз геройлары бар. «С.к.» балалар өчен төрле конкурс-бәйгеләр оештыра, «Тәмле тел» проектын тормышка ашыра. И.Әхмәдиев, Н.Әлмиев, Ф.Якупов, Ю.Денисов, И.Воробьев, А.Айсина, В.Фомин, Ф.Хәсьянова, З.Мөхәммәтҗанова, Л.Золондинова, З.Хәкимов, С.Ибраһимова һ.б. танылган рәссамнар б-н хезмәттәшлек итә. Төрле еллардагы баш рәссамнары: А.Үтәгәнов, Ф.Муллахмәтов, А.Юсупова. «С.к.» ж-лы ТР Журналистлар берлегенең «Бәллүр каләм» бүләге (1999, 2011), ТР Язучылар берлегенең А.Алиш исем. бүләге лауреаты.

**САЛАВА́Т РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасының* төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1935 елның 31 гыйнварында оештырыла. Мәйданы — 2182 *км*$^2$. Үзәге — Малаяз авылы (Уфадан 183 *км* көнчыгыштарак). Халкы — 24987 (2013), татарлар — 5934 кеше. С.р.нда — 60 торак пункт, шуларның 8 е — татар, 6 сы — башкорт-татар, 4 се башкорт-рус-татар, 1 се татар-рус торак пункты. Иң зур татар авыллары (2008) — Нәсибаш (1116) һәм Лаклы (1075 кеше). «Ниссе» (Нәсибаш а.) һәм «Әй моңнары» (Лаклы а.) татар вокаль ансамбльләре эшли. 2004/05 уку елында С.р.ның 1 мәктәбендә укыту татар телендә, 5 мәктәптә татар теле фән буларак укытыла. Язучы Н.С.*Исәнбәт*, тел галиме Ф.Ә.*Ганиевнең* тормышы С.р. б-н бәйле.

**САЛАВА́ТОВ** Ренат Салават улы (5.11.1950, Казакъстан ССР, Чимкент ш.), дирижёр, педагог, ТАССРның халык артисты (1980), РФнең атказ. артисты (2010). 1974 елда Ленинград консерваториясенең симф. дирижёрлык (К.Симеонов һәм И.Мусин класслары) ф-тын тәмамлый. 1974–75 тә Казакъстандагы Дәүләт телерадиосында Камера симф. оркестрының баш дирижёры, 1976–79, 1986–89, 2001–03 тә Казакъстан акад. опера һәм балет театры дирижёры, баш дирижёры һәм сәнгать җитәкчесе, бер үк вакытта Казакъстанның Дәүләт симф. оркестры дирижёры. 1979–85 тә Татар филармониясе симф. оркестры дирижёры. 1990–91 дә — С.М.Киров исем. опера һәм балет театры (С.-Петербург), 1991–96 да — Бавария дәүләт операсы (Германия, Мюнхен ш.), бер үк вакытта, 1994–2000 дә, Швеция Король операсы дирижёры. 2003 тән Татар опера һәм балет театрында; бер үк вакытта, 2006 дан — К.Байсәитова исем. Милли опера һәм балет театрының баш дирижёры һәм сәнгать җитәкчесе, 2007 дән Музыка академиясендә (Казакъстан, Астана) укыта. Дөньяның иң абруйлы концерт мәйданна-

рында, ш.и. Метрополитен-операда (АКШ, Нью-Йорк ш.), Инглиз милли операсында, Гранд-операда (Франция, Париж), Зур театрда (Мәскәү) чыгышлар ясый. Атаклы музыкантлар һәм артистлар (М.Плисецкая, Р.Аланья һ.б.) б-н эшли. Бразилия, Төркия, АКШ, Көнбатыш Европа илләрендә гастрольләрдә була. Репертуарын классик симф. һәм опера әсәрләре, ш.у. хәзерге авторларның симф., опера һәм балет әсәрләре буенча спектакльләрнең премьералары тәшкил итә. «Алкисса» (2006), «Кыз-Кыйялы» (2008) балетлары һ.б. муз. әсәрләр авторы. Казакъстанның «Курмет», «Достык» орденнары б-н бүләкләнә.


Р.С. Салаватов.

*Әд.:* Шведский дивертисмент России: Николай Вуколов. Ренат Салаватов. СПб., 2004; Народные артисты СССР, РФ, РТ. К., 2011.

**САЛАВАТУ́ЛЛИН** Габдулла Салават улы (17.8.1934, Апас р-ны Олы Кошман а.), механик жыю эшләре слесаре, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984). 1950–97 елларда «Радиоприбор» ЖБдә эшли. Дәүләт бүләге яңа машиналар һәм приборлар булдыруга зур өлеш керткәне һәм хезмәттәге югары казанышлары өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**САЛАВЫ́Ч СӘРДЕГӘНЕ́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 13 *км* көнчыгыштарак, Шушма елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 278 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 382,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Яңгул волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1859 да — 187, 1884 тә — 232, 1905 тә — 363, 1920 дә — 425, 1926 да — 437, 1938 дә — 450, 1949 да — 349, 1958 дә — 327, 1970 тә — 353, 1979 да — 302, 1989 да — 296, 2002 дә — 279 кеше.

**САЛАГА́ЕВ** Александр Леонидович (17.3.1952, Казан — 18.7.2014, Казан), социолог, социол. фән д-ры (2002), проф. (2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1975), Казан авиация ин-тының фәнни коммунизм кафедрасында эшли. 1979 елдан Казан ун-тында, социол. лаб-ясе мөдире (1986 дан). 1994 тән Казан технол. ун-тында, социаль һәм сәяси конфликтология каф. мөдире (2006 дан); бер үк вакытта, 2002 дән, Аналитик тикшеренүләр һәм хезмәтләр үзәге җитәкчесе. Тикшеренүләре хезмәт социологиясенә, хезмәт коллективлары мәсьәләләренә, яшьләр социологиясенә карый. Медаль б-н бүләкләнә. Рус мәдәнияте җәмгыяте рәисе (1992 дән).

Х е з м.: Молодёжные правонарушения и делинквентные сообщества сквозь призму американских социологических теорий. К., 1997; Государственное и муниципальное управление. К., 2004 (автордаш); Проблемы социальной девиации: В 2 ч. К., 2004.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. 2004. Т. 3.

**САЛАГЫ́Ш** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 73 *км* көньяктарак, Иж елгасы тамагы буенда. 2010 елда 623 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Авыл тарихы музее. Мәчет. 16–17 йөзләрдә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, балык тоту, киез итек-киез җитештерү, тимерчелек, сумала кайнату, агач эше, кәрзин үрү, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.та 3 мәчет, 5 сыйныфлы мәдрәсә (1916 да 115 укучы укый) була; базар эшли. 1909 да — татар халык китапханәсе, 1910 да рус-татар земство мәктәбе ачыла. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 12290,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Салагыш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 1726, 1887 дә — 2433, 1905 тә — 2959, 1920 дә — 3690, 1926 да — 2896, 1938 дә — 2023, 1949 да — 1323, 1970 тә — 1138, 1979 да — 556, 1989 да — 768, 2002 дә — 611 кеше.

*Әд.:* М ә р д а н о в Р.Ф., Һ а д и е в И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**САЛА́ЕВ** Юрий Николаевич (27.8.1945, Казан), инженер-электромеханик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002), ТРның атказ. машина төзүчесе (1993). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1968). 1962–2000 дә «Элекон заводы» АҖдә эшли: инженер, технол. бюро башлыгы, баш технолог урынбасары (1986 дан), баш инженер (1989 дан). 2000–02 дә «Казан оптик-механика заводы» АҖдә ген. директор. 2002–08 дә «Фотон» үзәк конструкторлык бюросы» Федераль дәүләт унитар пр-тиесендә директор, 2008 дән баш инженер. Дәүләт бүләге конкурентлыкка сәләтле күп функцияле яңа лазер мед. техникасын эшләгәне, җитештерүне оештыргагы һәм ТР мед. учреждениеләренә кертүгә өчен бирелә. Медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**САЛАМА́ТИН** Андрей Николаевич (19.6.1948, Казан), математик һәм механик, физика-матем. фән. д-ры (1989), проф. (1990), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, проректор (1989–92), гамәли матем. каф. профессоры (1992 дән). Хезмәтләре күп фазалы тирәлекләр механикасына, җылылык һәм масса күчерү процессларына, бозлыклар динамикасына һәм физикасына карый. С. гамәлдәге (нефть, газ һәм кудыру) скважиналарда тотрыксыз темп-ра режимы теориясенә зур өлеш кертә. Скважиналарны эксплуатацияләү шартларына карата күп фазалы агымнар теориясен үстерә. Боз капламнары динамикасы һәм боз ясалуның физик процесслары өлкәсендә тикшеренүләр үткәрә. Куыклы бозның тыгызлануы һәм реологиягә теориясен, бозда һәм бозлы порошокларда газ гидратлары барлыкка килү теориясен тикшерүгә зур өлеш кертә. Сезонлы 25 нче Антарктида экспедициясендә (1979–80) һәм Камчатка гляциология экспедициясендә (1986, 1988, 1997) катнаша.

Х е з м.: Температурные процессы в действующих скважинах. К., 1977 (автордаш); Математические модели дисперсных потоков. К., 1987; Air-Hydrate crystal growth in polarice // Journal of Crystal Growth. 2003. № 257.

**САЛАМЫ́К КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Идел елгасының югары террасасында, Лаеш р-ны Столбище авылыннан 4 *км* көньяктарак (даими яшәүчеләре булмаган Саламык авылы янында). Күл төньяктан көньякка таба сузынкы. Су өслегенең мәйданы 19,8 *га*. Су күләме якынча 800 мең $м^3$. Озынлыгы 1880 *м*, иң зур тирәнлеге 180 *м*. Уртача тирәнлеге 3,9 *м*, иң зур тирәнлеге 9 *м*. Күл карст процесслары нәтиҗәсендә хасил булган. Катлаулы, сузынкы формада. Ярлары күтәренке, урыны б-н текә, таллар б-н капланган. Туенуы күбесенчә грунт сулары исәбенә, тотрыклы. Язын кар эрегән вакытта, С.к.ндә су биеклеге арта һәм аның көньяк чигеннән инеш агып чыга. Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта, җиңелчә минеральләшкән (98 *мг/л*), йомшак (3,3 *мг-экв/л*), үтә күренмәлелеге 80 *см*, саргылт төстә. Ял итү максатларында һәм сугару өчен файдаланыла. ТРның табигать истәлеге (1978).


Саламык күле.

**САЛА́Т**, и г ү л е  л а т у к,  л а т у к  с а л а т (Lactuca sativa), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлек; яшелчә культурасы. Салкынга чыдам, су яратучан үсемлек. Үсемлекнең ыруг башлангычы булып компас латук санала (L. serriola). С. барлык Җир шары буйлап таралган. Төрле төрләре: яфрак С., кочанлы С., ромэн С. (кочане озынча формада). Барлык төрләре дә өске өлеше калынайган үзәк тамырлы. Яфраклары утырма, гади, тоташ яисә төрле дәрәҗәдә кискәләнеп, төрле формага кергән. Түбәнге яфраклары розеткага җыелган.

Яфраклары ачык яшелдән соры яшелгә кадәр, кызыл яисә көрән төстә. Чәчәк сабагы 60–120 *см* биеклектә, туры, тармакланган. Чәчәкләре вак, сары, кәрзин-чәчәк төркеменә җыелган. Җимеше 5–7 озынча кабыргалы яссы орлыкча, 2–6 *мм* лы, көмеш-соры һәм саргылттан куе көрән һәм кара төскә кадәр. Үсемлекнең барлык өлешендә дә сөтчел сыекча бар. Үзеннән серкәләнүче культура (көньяк районнарда читтән серкәләнү булырга мөмкин). Ачык һәм ябык грунтта үстерәләр. Үсеше өчен иң яхшы темп-ра 15–20°С, уңдырышлы комсу яисә җиңел балчыксыл туфракларда яхшы үсә. Яфраклы сортларын грунтка турыдан-туры чәчү, күчәнле сортларын рассада ысулы б-н һәм ачык грунтка чәчеп үстерәләр. Яфрак С. бер тапкыр җыела, күчәнле С.ны күчәне формалашуына карап җыялар.



Яфрак салат.

С. авырулары: соры һәм ак черек, ончыл һәм ялган ончыл чык, бактериоз, яфрак читләре көю, караяк, антракноз, мозаика, сеңерчәләр вирусы; С. корткычлары: ялангач лайлачлар, гөбләләр. ТРда чәчәргә рөхсәт ителгән сортлары — «Эре күчәнле» (1974) һәм «Верадари» (1990). «Майский», «Весенний» теплица хуҗалыкларында һәм йорт яны бакчаларында үстерелә. Азык буларак яфраклары салат яшелчәсе сыйфатында кулланыла. С. — аскорбин кислотасы, В, РР төркемнәре витаминнары, каротин, минераль тозларның кыйммәтле чыганагы.

*Әд.:* Овощеводство. М., 2003.

**САЛАТЧЫ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 43 *км* көньяктарак, Гөбенә елгасы буенда. 2010 елда 18 кеше (руслар) яши. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.да земство мәктәбе, 2 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 376 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Нурлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 88 ир-ат; 1959 да — 230, 1897 дә — 404, 1908 дә — 516, 1920 дә — 449, 1926 да — 430, 1938 дә — 413, 1949 да — 201, 1958 дә — 164, 1970 тә — 119, 1979 да — 82, 1989 да — 42, 2002 дә — 20 кеше.

**САЛАТЧЫ́ ШӘҺӘРЛЕГЕ́**, археол. истәлек; Гөбенә елгасының (Зөя елгасының сул кушылдыгы) уң ярындагы борынында, урта гасырлардагы (якынча 12–14 йөзләр) ныгытылган болгар торулыгы (шәһәре) калдыклары, Яшел Үзән р-ны Салатчы авылыннан 1 *км* көньяктарак. Шәһәрлекнең мәйданы 23 мең $м^2$. Беренче тапкыр С.М.Шпилевскийның археол. истәлекләр турындагы хезмәтендә искә алына (1877). Тикшеренүләр 19 йөзнең 2 нче яртысыннан Г.Н.Әхмәров (1891, 1909), Н.Ф.Калинин, А.Х.Халиков (1950), И.Л.Измайлов, А.М.Гобәйдуллин (1989–90) тарафыннан алып барыла. Археол. казулар барышында шәһәрлекнең уры, аның мәйданчыгының культура катламнары өйрәнелә. Шәһәрлек өч яктан текә ярлар б-н (биеклеге 8 *м* га якын) әйләндереп алынган, көнчыгышта кыр ягыннан — өч ур һәм борылмалы ике тирән чокыр рәвешендәге ныгытмалар системасы б-н чикләнә. Терр-ясе тигез булмаган сузынкы рәвештә, культура катламы 1 *м* га җитә һәм 2 горизонтка — монголларга кадәрге һәм Алтын Урдага караган өлешләргә бүленә. Әйбер материалын Имәнкискә һәм Болгар культурасына нисбәтле әвәләп ясалган чүлмәк ватыклары тәшкил итә. Г.Н.Әхмәров тарафыннан тупланган коллекциядә саргылт-алсу шифер орчык очлыгы саклана. Борындагы балчыклы туфракта борынгы фауна калдыклары (фаразланганча, мамонт сөякләре) табыла.

*Әд.:* Ш п и л е в с к и й С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; А х м а р о в Г. Городище Япанчино на Кубне // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1894. Т. 12, вып. 2; ш у л  у к. Отчёт о поездке с археологической целью летом 1909 года в Свияжский и Тетюшский уезды Казанской губернии // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1910. Т. 26, вып. 6; К а л и н и н Н.Ф., Х а л и к о в А.Х. Итоги археологических работ за 1945–1952 гг. // Тр. КФАН СССР. К., 1954; Ф а х р у т д и н о в Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и её территория. К., 1975; Археологическая карта Татарской АССР. Предволжье. К., 1985; Г у б а й д у л л и н А.М. Фортификация городищ Волжской Булгарии. К., 2002.

*А.М.Гобәйдуллин.*

**САЛАУ́З-МУХА́Н** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 7 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 432 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1701 дән Салаус исеме б-н билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1656,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иректе волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1816 да — 88 ир-ат; 1870 тә — 446, 1897 дә — 812, 1920 дә — 1026, 1926 да — 1001, 1938 дә — 866, 1949 да — 663, 1958 дә — 522, 1970 тә — 864, 1989 да — 522, 2002 дә — 434 кеше.

**САЛАУ́Ш**, к. *Әзи.*


**САЛА́Х** Әсгать Сәхап улы (5.1.1935, Беренче Май, хәзерге Әлмәт р-ны Түбән Абдул а.), язучы, журналист, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1992). Казан ун-тын тәмамлый (1967). 1965–90 елларда рус телендә чыккан «Знамя труда» г-тасы редакциясендә эшли, 1990–99 да «Әлмәт таңнары» г-тасын җитәкли. Төрле жанрларда яза. «Балыкчы малайлар» (1999) — хикәяләр, «Каеннар юлы» — повестьлар җыентыгы (2006), Чернобыль фаҗигасе б-н бәйле «Соңгы вальс» повесте (2013) авторы.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**САЛА́ХОВ** Ибраһим Низам улы (30.8.1911, Күкчәтау ш., хәзерге Казакъстан Респ-касы — 7.7.1998, Казакъстан Респ-касының Күкчәтау өлкәсе Кызылъяр а.), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1992). Казан пед. техникумын тәмамлагач (1931), «Яшь ленинчы», «Кызыл яшьләр» г-таларында, «Пионер» ж-лы редакциясендә әдәби хезмәткәр. 1935–37 елларда Казан пед. ин-тында укый. 1930 елларда яза башлый. «Ярату» пьесасы (1936), «Дуэль» повесте (1937), «Постта» шигырь җыентыгы (1937) һ.б. революцион романтика рухында иҗат ителгән. 1937 дә, «корткыч элемент» Г.Ибраһимов б-н элемтәдә булганы өчен гаепләнеп, атарга хөкем ителә. Соңрак хөкем карары 10 елга ирегеннән һәм аннан соң 5 елга гражданнар хокукларыннан мәхрүм итүгә үзгәртелә. Җәза срогын Колымада, Казан, Бөгелмә, Свердловск, Чиләбе, Төмән, Тобол төрмәләрендә үти. 1948 дә ирекkә чыга, 1956 да аклана.

Тоткынлыктан соң иҗат иткән әсәрләре, нигездә, автобиографик характерда. «Дала дулкыннары» (1957) лирик шигырьләр җыентыгы туган җир, аның табигате, яшьлек, мәхәббәткә багышлана. Тарих б-н кызыксына. Көндәлек матбугатта аның татар әдәбияты тарихы, мөһим вакыйгалар, билгеле шәхесләр турындагы язмалары басылып килә. Чирәм җирләрне күтәрүчеләргә багышланган «Күкчәтау далаларында» романында (1965), үзенең шәхси күзаллауларына нигезләнеп, совет системасының гаделсезлеген ачып бирә. «Төн кызы» (1971) җыентыгына тупланган хикәяләрендә, «Мәхәббәт картаямы?» (1980) повестенда казакъ авылларының гүзәл табигатен, халкының гореф-гадәтләрен, хезмәтен, бәйрәмнәрен матур итеп сурәтли. Балачак хатирәләренә нигезләнеп язылган «Аристократ» (1969), «Тәүфыйксыз бала» (1969), «Яңа маҗаралар» (1971), «Яшел йортның тарихы» (1978) әсәрләре балаларны казакъ далаларының табигате, хайваннар дөньясы, көндәлек тормышы б-н якыннан таныштыра. «Имәннәр тамыр җәйгәндә» (1986) тарихи роман-эпопеясы Казакъстанда Октябрь рев-циясе вакыйгаларына багышлана. Тәнкыйтьләнүгә карамастан, роман татар әдәбияты тарихында Казакъстан татарларының совет хакимияте өчен көрәшен тарихи яктан дөрес тасвирлаган беренче әсәр булып кала. Автор бигрәк тә татар әдәбиятында беренчеләрдән булып ГУЛАГ темасын яктырткан «Колыма хикәяләре» (1989; икенче исеме «Тайгак кичү»; рус теленә тәрҗемәсе «Черная Колыма», 1991) автобиографик романы б-н таныла. Роман ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә лаек була (1990), Казан татар яшь тамашачылар театры сәхнәсендә куела (1995). Гомеренең соңгы елларында С. кабат тарихка мөрәҗәгать итә. Аның «Күк-

чәтау татарлары» (1995) исемле публицистик мәкаләләр җыентыгы Казакъстан татарлары тарихы буенча мөһим чыганак булып тора. С.ның тәрҗемә өлкәсендә дә хезмәтләре бар. Ул М.Светлов, А.Прокофьев, С.Сейфуллин, И.Жансогыров һ.б.ның әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Казакъстан Респ-касының «Парасат» ордены б-н бүләкләнә.



И.Н. Салахов.

*Әд.:* Минһаҗева Л. Ибраһим Салахов иҗаты. К., 1999.

*Г.М.Габделхакова, Л.И.Минһаҗева.*

**САЛӘ́ХОВ** (Сәлахов) Булат Нуретдин улы (21.3.1952, Арча р-ны Алан а.), актёр, ТРның халык артисты (2009). Кукмара һөнәри-техник уч-щесен тәмамлаганнан соң, КамАЗда төзүче-эретеп ябыштыручы булып эшли. Проф. сәхнәгә Чаллы шәһәрендәге «Энергетик» мәдәният йорты каршындагы үзешчән театр коллективыннан килә. 1988 елда, Казан мәдәният ин-тының режиссёрлык ф-тын тәмамлаганнан соң, үз коллективында шактый гына спектакльләр куя. 1990 нан Чаллы татар драма театры актёры. Актёрларга хас мөлаемлыгы, эчкерсезлеге, сәхнәдәге табигыйлеге С.ка тирән эчтәлекле, психол. яктан баетылган, тышкы кыяфәтләреннән үк кызыксыну уята торган образлар иҗат итәргә мөмкинлек



Б.Н. Саләхов Рифат ролендә («Корт», Ф. Галиев; Сәлимә ролендә – Э. Шиһапова).


бирә. Алар арасында Нурми («Күбәләк булып җаның кайтыр», Р.Батулла), Айрат («Су буенда учак яна», Ф.Галиев), Өмет («Гашыйклар тавы», И.Юзеев), Шаехмирза, Надир мәхдүм («Американ», «Сүнгән йолдызлар», К.Тинчурин), Кыйтфир («Йосыф», Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре буенча) — шундыйлардан. З.Хәкимнең «Сулкылдап елый җаннар» драмасындагы Илдар образын уңышлы иҗат иткәне өчен, К.Тинчурин исем. Респ-ка театр фестивале лауреаты исеменә лаек була (1994). Актёр иҗатында әкият геройлары да, лирик һәм комик образлар да бар: Шамакай («Түләк һәм Сусылу», Н.Исәнбәт), Ильяс («Кодача», З.Исмәгыйлев), Бәдри («Галиябану», М.Фәйзи), Хәмди («Булмас димә», Т. әл-Хәким), Сиражетдин («Банкрот», Г.Камал), Сәлмән («Җен бутады», З.Хәким), Рифат («Корт», Ф.Галиев) һ.б. Концерт эшчәнлеге б-н шөгыльләнә, аерым алганда, җырчы С.Фәтхетдинов концертларын алып бара; режиссёр буларак, Чаллыда уза торган күп кенә бәйрәм чараларын («Сабантуй гүзәле», «Татар егетләре») оештыра. Чаллы һәм Минзәлә татар драма театрлары сәхнәләрендә куелган «Җәмилә авылы», «Яр» («Кеше турында новелла») пьесалары авторы. Д.Сираҗиев исем. театраль бүләк лауреаты (2011).

*Д.Ә.Гыймранова.*

**САЛДАКА́Й** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 22 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 462 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 62%, татарлар — 37%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1717 дән чуаш авылы Тиханкова буларак билгеле, 1813 тә биргә татарлар килеп урнаша. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Тиханово-Салдакаево исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1898 дә ачыла), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1452 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Егоркино волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 186 ир-ат; 1859 да — 492, 1897 дә — 662, 1908 дә — 688, 1920 дә — 909, 1926 да — 797, 1938 дә — 792, 1949 да — 726, 1958 дә — 719, 1970 тә — 908, 1979 да — 746, 1989 да — 431, 2002 дә — 491 кеше.

**САЛИӘХМӘ́Т** Мәдинә Хөсәен кызы (12.12.1897, Уфа ш. — 22.5.1964, Истанбул ш., Төркия), җәмәгать эшлеклесе, журналист. 1 нче башкорт хөкүмәте әгъзасы И.Х.Әсәкәевнең сеңлесе. 1917 елгы рев-ция вакытында Петербург ун-тындагы укуын туктатып тора. 1920 дән Кытайда: «Гыйният» (Харбин ш.) татар милли мәктәбендә укыта, 1934 тә Шанхай шәһәренә күченеп китә һәм, милли мәктәп оештырып, шунда татар теле һәм мәдәнияте укыта. Мөселман хатын-кызлары арасында мәдәни-агарту эшчәнлеге алып бара. «Милли байрак» татар г-тасында языша, «Кадыйр», «Рөстәм», «МА», «Ш.Б.», «З.А.» тәхәллүсләре һ.б. б-н «Ерак Шәрекъ» ж-лында, рус телле «Шанхайская заря», «Слово» һ.б. газеталарда мәкаләләрен бастыра. «Шанхай төрки-татарларының Идел-Урал комитеты» җитәкчеләренең берсе, «Идел-Урал, Украина, Кавказ халыкларын азат итү комитеты» вице-президенты. С. уйгыр-татар-рус-кытай сүзлеген әзерләүдә катнаша. Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң Төркиягә күченеп китә. Хезмәтләре татар халкы тарихы һәм мәдәниятенә карый.

*Әд.:* Усманова Л. Тюрко-татарская эмиграция Дальнего Востока // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2007. № 2.



Б.Н. Саләхов.



М.Г. Салигаскәрова.

**САЛИГАСКӘ́РОВА** Мәгафура Галиулла кызы (20.11.1922, БАССРның Бәләбәй р-ны Ихсан а., хәзер БРның Чакмагыш р-ны – 7.10.2015, Уфа), җырчы (меццо-сопрано), БАССР, РСФСРның халык артисты (1951, 1957). 1941–42 елларда Мәскәү консерваториясе каршындагы Башкорт опера студиясендә укый. 1938–72 дә Башкорт опера һәм балет театры солисты. Төп партияләре: Азучена, Амнерис («Трубадур», «Аида», Дж. Верди), Кармен (шул исем. әсәр буенча, Ж.Бизе), Любаша («Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Кончаковна («Князь Игорь», А.Бородин), Ольга һәм Няня, Любовь, Полина («Евгений Онегин», «Мазепа», «Пики дамасы», П.Чайковский), Тугзак («Алтынчәч», Н.Җиһанов) һ.б. Башкорт композиторлары операларындагы Айсылу («Сакмар», М.Вәлиев), Яланбикә («Давыл», Р.Мортазин), Яубикә, Көнбикә («Шәүрә», «Салават Юлаев», З.Исмәгыйлев) һ.б. партияләрне беренче башкаручы. Җырчының концерт репертуарын рус һәм чит ил, башкорт һәм татар композиторларының әсәрләре, башкорт һәм татар халык җырлары тәшкил итә. 1 нче Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивале лауреаты (Прага, 1947).

*Әд.:* Хайруллин Р. Мастера оперного искусства Башкирии. Уфа, 1967.

**САЛИ́ЕВ** Пулат (Бикбулат) Мәҗит улы (1882 — 28.2.1938), тарихчы, Үзбәкстанда заманча тарих фәненә нигез салучыларның берсе. «Низамия» (Әстерхан ш.) мәдрәсәсендә укый, «Мөхәммәдия» (Казан, 1905), «Галия» (Уфа, 1909) мәдрәсәләрен тәмамлый. Г.Гомәри, З.Камали һ.б.ның шәкерте була. 1909 елдан Урта Азия мәктәпләрендә, 1913 тә Ташкентта рус-татар уч-щесендә укыта, аннан соң Коканд шәһәрендә Укытучылар семинариясе директоры. «Ил» (Мәскәү) г-тасы һәм «Шура» ж-лында очерк-мәкаләләр бастыра. 1913, 1917 дә Ә.*Вәлиди* б-н очраша, хат алыша. 1917 дә Төркестанның киләчәк дәүләт төзелеше, Коканд шәһәрендә дәүләт хакимиятенең яңа системасын («Туркистон мухторияти») оештыру турындагы бәхәсләрдә катнаша. Вакытлы хөкүмәт рәисе А.Ф.Керенский тарафыннан кабул ителә (аның б-н С. Төркестан уч-щеләре баш инспекторы булган дәвердә таныша), ул вакытта Керенский Урта Азия халкының халык мәгарифе программасын тормышка ашыруда ярдәм күрсәтергә вәгъдә бирә. С. Төркестан Вакытлы Советы һәм Төркестан Халык җыены составына керә, радикаль реформаларны һәм хакимият органнарында тиңдәшле этник вәкиллек

идеяләрен яклый. «Ил байрагы» г-тасының баш мөхәррире. Төркестан автономиясе таркатылганнан соң, С. сәяси эшчәнлектән ераклаша. 1918 дә Төркестан Мәгариф халык комис-ты учреждениеләрендә эшли, Коканд шәһәрендә халык ун-ты, Ферганәдә укытучылар әзерләү курслары оештыруда катнаша. Төрки-татар мәгариф ин-тын (Ташкент) оештыручы һәм беренче директоры. ВКП(б)ның Төркестан ҮК ж-лы «Инкилоб»ның җаваплы мөхәррире. 1922 дән Бохара Совет Халык Респ-касының Мәгариф назирәте (Мәгариф халык комис-ты) Фәнни советы рәисе. Бер үк вакытта Укытучылар ин-тында гарәп әдәбияты һәм теле укыта, «Мәгариф вә мәдәният» ж-лы (1923–24, Бохара) мөхәррире. Бохарада эшләү дәверендә беренче булып Бохара әмирләренең китапханәсен һәм архивын тәртипкә китерүдә катнаша. 1924 тә Мәскәүгә, Бохара мәгариф йортында укытырга җибәрелә. 1924 нең ахырыннан СССР халыклары Үзәк нәшриятының Урта Азия секциясе фәнни хезмәткәре, 1926 да Кызыл профессура ин-ты курсын тәмамлый; Урта Азия кулъязма ядкәрләре фондын оештыруда катнашу өчен, Мәскәүдән Үзбәкстанга чакыртып алына. С. үзбәк язуын гарәп графикасыннан латинга күчерүгә каршы тора. 1927 дән Сәмәрканд пед. ин-тының Урта Азия тарихы кабинеты мөдире, Үзбәкстан тарихы укытучысы, проф. (1931 дән). 1932–33 елларда ВКП(б)ның Үзбәкстан ҮК каршындагы Үзбәкстан рев-ция һәм партия төзелеше фәнни-тикшеренү ин-тында (Ташкент) эшли. 1935 тә Үзбәк ун-тының (Сәмәрканд ш.) Урта Азия тарихы кафедрасын оештыручыларның берсе һәм беренче мөдире. 1936 да Үзбәкстан ҮБК каршындагы Фәннәр ком-тында Үзбәкстан тарихы секциясен җитәкли. Үзбәк телендә Урта Азия тарихыннан «Мангытлар династиясе дәверендә Бохара» (Таш., 1920), «Урта Азия тарихы» (Сәмәрканд-Таш., 1926), «Урта Азиядә сәүдә капиталы дәвере» (Таш., 1926), «Урта Азиядә ислам дине таралу» (Сәмәрканд-Таш., 1928) хезмәтләре авторы. Иң зур хезмәте — «Үзбәкстан тарихы. XV йөз — XIX йөзнең 1 нче яртысы» (Сәмәрканд-Таш., 1929). Хезмәттә Үзбәкстан тарихы һәрьяклап анализлана, төп игътибар Төркестан халыкларының иҗтимагый-сәяси һәм социаль-икътисади тарихына юнәлдерелә. Төркестан тарих җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы. Репрессияләр корбаны.

*Әд.:* Т е р д ы е в Ш. Среднеазиатские татары: роль и значение в культурной и политической жизни Туркестана первой четверти XX в. // Панорама-Форум. 1997. № 12; Г е р м а н о в В.А. Профессор Пулат Салиев и его время. Таш., 2002.

*Р.Х.Әхмәтҗанов.*

**САЛИ́ЕВ** Ринат Әхмәдулла улы (5.9.1965, Омск ш.), стоматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (2002), ТРның атказ. табибе (2000). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1987), шунда ук, ортопедик стоматология кафедрасында калдырыла. 1993 елдан 5 нче стоматология поликлиникасы табибе (Казан). 1999 да Казан техник ун-тын тәмамлый. 2004 тән «5 нче стоматология поликлиникасы» АҖ ген. директоры. ТР Стоматология ассоциациясе вице-президенты (2003 тән). Хезмәтләре стоматология ярдәме күрсәтүне оештыру мәсьәләләренә; җитештерүнең сәламәтлеккә зыянлы төрләрендә эшләүчеләрнең теш һәм теш рәтләре дефектларын ортопедик дәвалауга карый. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Организационные и методические основы управления ортопедической стоматологической помощью: Учеб. пособие. К., 2004 (автордаш).

**САЛИ́ЕВА** Гөлшат Тәүфикъ кызы (23.4.1968, Казан), стоматолог, мед. фән. д-ры (2004). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1990), шунда ук, ортопедик стоматология кафедрасында эшли. Хезмәтләре ортопедиягә (денталь имплантологиядә остеопороз, эксперим. модельләштерү), ортодонтик дәвалауга карый. Уйлап табуга 5 патенты бар.

Х е з м.: Структура костной ткани и динамика репарации кости в эксперименте после операции имплантации при остеопорозе // Стоматология для всех. 2003. № 3 (автордаш).

**САЛИ́ЕВА** Роза Наил кызы (29.6.1957, Амур өлкәсенең Сковородинский р-ны Ерофей Павлович пос.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (2004), проф. (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1980). 1980–84 елларда Серго исем. з-дта юрисконсульт (Зеленодольск ш). 1985–2005 тә Төмән шәһәрендә: эшчеләр тәэминаты терр. идарәсендә (1987 гә кадәр), блок-комплект җайланмалар з-дында (1987–89), «Фонд» компаниясендә (1991–92), Үзәк р-ны хакимиятендә (1992–94), «Лаптев һәм партнёрлар» компаниясендә (1994–96) юрисконсульт; Хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү ин-тында (1989–91), Төмән ун-тының гражданлык хокукы һәм процессы, эшмәкәрлек һәм хезмәт хокукы кафедраларында (1996–2004) укытучылык хезмәтендә; РФА Себер бүлеге Төмән фәнни үзәгенең хокукый проблемалар бүлеге мөдире (2004–05). 2005–08 дә Икътисад, идарә һәм хокук ин-тының (Казан) эшмәкәрлек хокукы каф. мөдире. 2008 дән ТР ФА Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары ин-тының экология һәм җир асты байлыкларын файдалануның хокукый проблемалары лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре гражданлык, тау эшләре хокукын өйрәнүгә, ягулык-энергетика комплексында хуҗалык мөнәсәбәтләрен хокукый җайлау мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Правовое регулирование отношений собственности в сфере поиска, разведки и добычи минерального сырья в Российской Федерации (на примере нефти и газа). Новосиб., 2000; Гражданское право: В 2 т. Тюмень, 2001; Правовое обеспечение развития предпринимательства в нефтегазовом секторе экономики. Новосиб., 2001; Горное право: В 2 ч. К., 2006 (автордаш).

**САЛИ́ТОВА** Фәридә Шәриф кызы (12.6.1948, Австрия, Вена), музыка белгече, пианист, педагог, пед. фән. д-ры (2003), проф. (2008), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1996), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2010). ТР Композиторлар берлеге әгъзасы (1992). Казан консерваториясен фортепиано буенча (С.Ә.Гобәйдуллина классы) тәмамлый (1971). Казанның 3 нче балалар музыка мәктәбендә; 1973 елдан Казан мәдәният ин-тында укыта. 1983–85 тә Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында. 1985 тән Татар гуманитар пед. ун-тында, 2000–10 да музыка ф-ты деканы һәм музыка теориясе, тарихы һәм музыка белеме методикасы каф. мөдире; бер үк вакытта, 1998–2013 тә, ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында. 2013 тән Мәскәүдә яши. Хезмәтләре татар музыкасы, музыка педагогикасы һәм муз. белем бирүгә карый, Татар энциклопедиясендә Татарстанда муз. культура һәм музыка сәнгате тарихы буенча мәкаләләр авторы һәм кураторы.

Х е з м.: Формирование традиционной музыкально-педагогической культуры татарского народа (VI–XVI вв.). К., 2001; Развитие музыкально-педагогической культуры Казанского края (середина XVI — начало XX вв.). К., 2002; Развитие музыкально-педагогической культуры татарского народа (от истоков до начала XX в.). К., 2002; История татарской музыкальной педагогики. К., 2008; Музыкально-педагогические традиции татарского народа. К., 2008; Салих Сайдашев: Жизненный и творческий путь. К., 2011.

**САЛИ́Х** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 55 *км* көньяктарак, Оренбург өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 170 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.та волость идарәсе урнаша; мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1026,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Салих волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1859 да — 381, 1889 да — 533, 1897 дә — 630, 1910 да — 838, 1920 дә — 872, 1926 да — 969, 1938 дә — 772, 1958 дә — 551, 1970 тә — 488, 1979 да — 363, 1989 да — 212, 2002 дә — 205 кеше.

**САЛИ́Х әл-КИЛИ́** (?, Казан губ., Казан өязе Кили а. — 19 йөзнең 1 нче яртысы), дин эшлеклесе. Руханилар нәселеннән. Дин гыйлемен Бохарада ала. Казан губернасы Казан өязенең Иске Кенәр авылында имам һәм мөдәррис була, соңрак Казандагы Апанай мәчете каршында мәдрәсә ача. Хезмәтләре илаһият гыйлеменә карый.

*Әд.:* М ә р җ а н и Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар. К., 1989.

**САЛИ́Х ТАВЫ́**, табигать истәлеге. Баулы р-ны Салих авылыннан төньяк-көнчыгыштарак. Кунна елгасы (Югары Кандыз елгасының сул кушылдыгы) үзәненең уңъяк сөзәклегендә известьле токымнардан торучы калкулыклы участокны били. 1989 елда билгеләнә. Мәйданы 30 *га*. Ташлы, куакчыл, болын-дала төркемнәре үсемлекләре үсә. 220 дән артык үсемлек, шуның 72 се ТРның Кызыл китабына кертелгән: татар катраны, эре чәчәкле тәңкәяфрак, ике башаклы тау тамыры, Альп арыш гөле, сырлы вайда (биредә генә очрый) һ.б. Тәңкәканатлыларның сирәк төрләре яши.

**САЛИ́Х-ТУКА́Й** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ургыды елгасы башланган урында урнашкан. 2010 елда 25 кеше (татарлар) яши. 20 йөз башында нигез салына, 1960 ларга кадәр Салих буларак билгеле. Оештырылган көненнән Уфа губернасының Минзәлә өязе Бишенде-Останково волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Сарман, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1920 дә — 90, 1926 да — 92, 1949 да — 178, 1958 дә — 148, 1970 тә — 74, 1979 да — 37, 1989 да — 22, 2002 дә — 13 кеше.

**САЛИХА́НОВ** Рәүхат Салихан улы (4.10.1948, Актаныш р-ны Иске Байсар а.), галим агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. агрономы (1983), РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1999). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1972). 1966 елдан (бүленеп) Актаныш р-нының Шәймәрданов исем. к-зында (2003 тән «Ташкын» ҖЧҖ) эшли, тракторчылар бригадасы хисапчысы, агроном, колхозның баш агрономы (1972 дән), район башкарма ком-тының а.х. идарәсендә баш агроном (1977 дән), колхоз рәисе (1983), ҖЧҖ рәисе (2003 тән). С. җитәкче булганда, колхозда җитештерүнең 30 объекты һәм мәдәният-көнкүреш биналары төзелә. Авылга газ кертелә. 1983–2007 дә хуҗалыкта бөртекле ашлык җитештерү 57,5% ка, ит — 54,4% ка, сөт 2,1 тапкыр арта. 2007 дә бөртеклеләрнең уңышы 1 *га* дан 72,4 *ц* га, еллык савым һәр сыердан уртача 5128 *кг* га җитә. Медаль б-н бүләкләнә.

**САЛИХҖА́НОВА** Рәшидә Мөхәммәтфатих кызы (5.1.1933, Мәскәү — 10.6.2012, шунда ук), приборлар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1983), проф. (1986), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2002). 1 нче Мәскәү чит телләр пед. ин-тын (1957), Мәскәү энергетика ин-тын (1960) тәмамлый. 1960–75 елларда Бөтенсоюз кара металлургияне автоматлаштыру фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү); 1975 тән Мәскәү радиотехника, электроника һәм автоматика ин-тында эшли. Хезмәтләре полярографик һәм вольтамперометрик анализ алымнары өчен серияле приборлар комплексы булдыруга карый. С. электрохимик анализ ысуллары теориясенә, практикасына һәм аларны аппаратлар б-н тәэмин итүгә зур өлеш кертә, бу алымнар металлургия сәнәгатенә, медицинага һәм әйләнә-тирәнең пычрануын билгеләүгә актив кертелә. Уйлап табуга 14 авторлык таныклыгы бар.



Салих тавы.

Х е з м.: Современные методы определения атмосферных загрязнений населённых мест. М., 1980 (автордаш); Практикум по электрохимическим методам. М., 1983 (автордаш); Вольтамперометрия переменного тока. М., 1985; Полярографы и их эксплуатация в практическом анализе и исследованиях. М., 1988 (автордаш).

**САЛИ́ХОВ** Әхәт Салих улы (3.3.1938, Арча р-ны Наласа а.), галим агроном, а.х. фән. канд. (1970), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006), ТАССРның атказ. агрономы (1982), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995). Ключище а.х. техникумын тәмамлый (1956). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), шунда ук эшли (бүленеп): өлкән укытучы, игенчелек каф. доценты, проректор (1984–88), гомуми игенчелек каф. мөдире (2002–09). 1998–2002 дә Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында директор урынбасары. Дәүләт бүләге ТР игенчелегенә биол. факторлар нигезендә ресурс саклаулы технологияләр эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Севообороты: агроэкономические основы, пути усовершенствования. К., 1977; Рекомендации по организации севооборотов в условиях специализации земледелия. М., 1986 (автордаш).

**САЛИ́ХОВ** Бәдигъ Мөхәммәт улы (28.2.1910, Уфа губ., Минзәлә өязе Октябрь а. — 23.7.1956, Мамадыш р-ны Дусай а.), Дан орденының тулы кавалеры (8.5.1944, 6.9.1944, 29.6.1945), старшина. 1922 елдан Дусай авылында яши. Колхоз рәисе булып эшли. 1941 нең июненнән Кызыл Армия сафларында һәм Бөек Ватан сугышы фронтларында, 574 нче укчы полкында миномёт ротасы расчёты командиры (38 нче армиянең 121 нче укчы дивизиясе). Көньяк-Көнбатыш, Воронеж, 1 нче һәм 4 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Донбасс оборона операциясендә (1942), Воронеж-Кастория (1943), Житомир-Бердичев (1944) һәм Львов-Сандомир (1944) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 24 мартында Волковцы торак пункты (Чортков шәһәреннән көньяк-көнчыгыштарак, Украина ССР) янында контрһөҗүмне кире кайтарганда батырлык күрсәтә: автоматы б-н дошманның 4 солдатын, миномёт ноктасын һәм расчётын юк итә; 1944 нең 24 июлендә Дунаево авылы өчен сугышта (Львов шәһәреннән көньяктарак) С. җитәкчелегендә расчёт дошманның пулемёт ноктасын һәм бер взводтан артык солдатын юк итә, 2 йөк автомашинасын сафтан чыгара; 1945 нең 15 гыйнварында Петрувка торак пункты (Кросно шәһәреннән көнбатыштарак, Польша) янында дошманның 2 пулемёт ноктасын, сугыш кирәк-яраклары олавын һәм 10 солдатын юк итә. Сугышчыларны Бельско-Бяла шәһәренә (Польша) кучергәндә, С. расчёты пехота сафларында була һәм, ут ачып, укчы подразделениегә юлны чистарта. Бу сугышларда расчёт дошманның бер отделениедән күбрәк җанлы көчен һәм сугыш кирәк-яраклары төялгән 4 олавын, автомашинасын юк итә. 1945 тә демобилизацияләнә. Дусайга кайтып, колхоз рәисе булып эшли башлый. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә. 1945 тә Җиңү парадында катнаша. Дусай авылында С.ка һәйкәл куела, урта мәктәп аның исемен йөртә.



Б.М. Салихов.



Г.С. Салихов.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**САЛИ́ХОВ** Борис Варис улы (3.6.1956, Констанца ш., Румыния), икътисадчы, полковник, икътисад фән. д-ры (1996), проф. (2000). Новосибирск югары хәрби-сәяси академиясен (Мәскәү, 1985) тәмамлый. 1977–82 елларда Совет Армиясендә. 1985–99 да В.И.Ленин исем. Хәрби-сәяси академиядә, бер үк вакытта, 1994–96 да, РФ Оборона министрлыгы Хәрби ун-тында политэкономия каф. укытучысы. 1999 дан Мәскәү гуманитар-икътисад ин-тында икътисад теориясе каф. мөдире һәм проректор. Фәнни тикшеренүләре милек теориясе мәсьәләләренә карый (соц.-икътисади һәм институцион аспектлар). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Экономическая теория. М., 2001.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**САЛИ́ХОВ** Владимир (Вазыйх) Салих улы (5.12.1941, Чита өлкәсенең Карымское пос.), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1996), проф. (1998). Иркутск ун-тын тәмамлый (1965). Чита шәһәрендә эшли: 1965 елдан Байкал аръягы комплексы фәнни-тикшеренү ин-тында, 1971 дән Бөтенсоюз алтын фәнни-тикшеренү һәм проект ин-тында, 1976 дан Чита техник ун-тында. Хезмәтләре геол. һәм файдалы казылмаларга карый. С. руда барлыкка килүнең геотектоник цикллар б-н бәйле булуы турындагы фаразны әйтә, рудалашу концентрациясенә руда барлыкка килү мохитенең катастрофизмы һәм активлыгы тәэсирен тикшерә, кызыл төстәге утырмаларны типлаштыра һәм бакыр рудасы барлыкка килү процессының синергетик моделен эшли, Чита өлкәсенең аерым регионнарында углеводород чималы перспективаларын нигезли.

Х е з м.: Медистые песчаники и сланцы мира. М., 1983 (автордаш); Основные проблемы современной геологии. Чита, 2006.

*Әд.:* Энциклопедия Забайкалья. Новосиб., 2006.

**САЛИ́ХОВ** Гатаулла Салих улы (1.1.1924, Арча кантоны Түбән Оры а. — 16.2.2012, Мәскәү), Сов. Союзы Герое (27.8.1943), өлкән лейтенант. Ташкент пехота уч-щесенең тизләтелгән курсларын (1943), «Выстрел» курсларын (Мәскәү өлкәсенең Солнечногорск ш.,

1944) тәмамлый. Туган авылында колхозда эшли. 1942 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 518 нче укчы полкта отделение командиры (63 нче армиянең 129 нчы укчы дивизиясе). Брянск, Үзәк һәм Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Орёл, Брянск һәм Гомель-Речица һөҗүм операцияләрендә катнаша (барысы да — 1943 тә). Зур Малиновец һәм Сетуха (Орёл өлкәсе Залегощь р-ны) авыллары янындагы сугышларда батырлык күрсәтә: 1943 нең 12 июленнән 3 августына кадәр дошманның 40 тан артык солдатын юк итә. Сугышның хәлиткеч мизгелләрендә башта — взвод командирын, аннары, рота командирын алыштырып, сугышчыларны дошманга каршы штык һөҗүменә күтәрә. 1945 тән запаста. Мәскәүдә яши. Бөтенсоюз «Энергопром» фәнни тикшеренү ин-тында эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәренең бер урамына С. исеме бирелә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

**САЛИ́ХОВ** Данил Хәбибрахман улы (7.10.1958, Актаныш р-ны Киров исем. совхоз пос.), драматург, актёр, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2000). Казан театр уч-щесен тәмамлагач (1983), Татар акад., Татар драма һәм комедия театрлары актёры (1985–93). 1993–98 елларда ТР Язучылар берлеге рәисе урынбасары, 2003–06 да Татарстан интеллектуаль милек агентлыгы (ТАИС) директоры. 2006–10 да ТР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлегендә җаваплы сәркәтип. 2012–2016 да ТР Язучылар берлеге рәисе урынбасары, 2016 дан ТР Язучылар берлеге рәисе. Татар акад. театры сәхнәсендә уйналган Алмазбулат (Ю.Сафиуллинның «Алмазбулат» пьесасы, 1983), Тимур (Р.Мингалимнең «Кайда сез, ирләр?» пьесасы, 1983); Татар драма һәм комедия театры сәхнәсендә — Басарый (Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар», 1987) рольләре иң уңышлыларыннан. «Туй күлмәгем — соңгы бүләгем» (Татар драма һәм комедия театры, 1988), «Яшьлек хатам — йөрәк ярам» (шунда ук, 1989), «Бәйрәмгалинең сыер тышавы» (шунда ук, 1990), «Алла каргаган йорт» (Әлмәт татар драма театры, 1991), «Никүләй дәдәйнең бөер ташы» (Минзәлә татар драма театры, 1992), «Хатын түгел — аждаһа» (Әлмәт татар драма театры, 1992), «Сәер кеше» (шунда ук, 2008) пьесалары авторы. Әсәрләре «Яшьлек хатам — йөрәк ярам» (1998), «Гыйлаж тәрәзәләре» (2004), «Пьесалар» («Пьесы», 2008, рус телендә), «Таш сандык» (2008), «Ак күгәрсен» (Өфө, 2012, башкорт телендә) җыентыкларына тупланган. ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләге лауреаты (2005).

*Әд.:* Шәмсутова А.А. Хәзерге татар әдәбиятында яңарыш: фәнни мәкаләләр. К., 2010; Закирҗанов Ә.М. Рухи таяныч: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. К., 2011; Саттарова А.М. Современная татарская драматургия: 1985–2000 гг. Концепция эпохи и героя. К., 2003.

**САЛИ́ХОВ** Илгиз Мисбах улы (5.9.1953, Сарман р-ны Әлмәт а.), инженер-геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999), техник фән. канд. (2001), РФнең атказ. геологы (1998). 2014 елдан ТР Дәүләт Советы депутаты. Казан ун-тын тәмамлый (1976). 1975–76 да «Азнакайнефть» НГДУында скважиналарны җир астында ремонтлау буенча оператор, 1976–2003 тә «Җәлилнефть» НГДУында скважиналарны тикшерү буенча оператор, инженер, промысел тикшерүләре төркемендә өлкән геолог, цех башлыгы урынбасары, цех башлыгы, цехта өлкән геолог, технол. бүлеге башлыгы, баш геолог (1992 дән), 2003 тән «Татнефть» АҖнең «Нурлатнефть» НГДУы башлыгы. Уйлап табуга 22 патенты бар. Дәүләт бүләге Татарстанның авыр чыгарыла торган нефть запаслары чыганакларында ятмаларның нефть бирүчәнлеген арттыру технологиясе комплексын эшләүдә һәм житештерү процессына кертүдә катнашканы өчен бирелә. СССР Нефть сәнәгате министрлыгы премиясе лауреаты (1989). Медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Хезм.: Влияние глинистости пласта-коллектора на его физико-гидродинамические характеристики // Нефтепромысловое дело. 1999. № 11 (автордаш); Совершенствование изучения геологической модели с помощью автоматизированных корреляционных разрезов // Нефтяное хоз-во. 2001. № 8 (автордаш); Особенности разработки залежей нефти терригенных и карбонатных коллекторов месторождений НГДУ «Нурлатнефть» // Нефтяное хоз-во. 2004. № 7 (автордаш).

**САЛИ́ХОВ** Илдар Газыймҗан улы (19.6.1941, Казан — 27.7.2011, шунда ук), терапевт, мед. фән. д-ры (1992), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1996), ТАССРның һәм РФнең атказ. табибе (1991, 1995). Профессорлар В.Е.Анисимова һәм З.И.Малкин шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1964), шунда ук, факультет терапиясе кафедрасында эшли; 1983 елдан 1 нче эчке авырулар каф. мөдире, проф. (1992). Хезмәтләре атеросклерозны һәм коронар кан тамырлары зәгыйфьләгән дәвалауга карый. Беренче булып ревматоидлы артрит очрагында нейтрофиллар реактивлыгы бозылуын ачыклый. Церебраль васкулитларга диагноз кую принципларын эшли. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм 2 патенты бар. ТР дәүләт бүләге «ТРда ревматизмны дәвалау хезмәтен камилләштерүнең фәнни-гамәли һәм оештыру аспектлары» («Научно-практические и организационные аспекты совершенствования ревматоидной службы в РТ») хезмәте өчен бирелә (2000).

Хезм.: Тактика терапевта при экстрагенитальной патологии беременных. К., 1976; Тактика терапевта в хирургической клинике. К., 1985 (автордаш); Принципы диагностики церебральных васкулитов. К., 2001.

*Әд.:* Профессор Ильдар Газимджанович Салихов // Казан. мед. журн. 1967. № 4.

**САЛИ́ХОВ** Ирек Галимҗан улы (25.3.1927, Буа ш.), хирург, мед. фән. д-ры (1970), проф. (1972), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1975). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), Ютазы р-ны Кырымсарай участок хастаханәсендә баш табиб булып эшли. 1955 елдан Казан мед. ин-тында, 1969 дан госпиталь хирургиясе каф. мөдире, бер үк вакытта проректор (1970–75). 1983–92 дә хирургик авырулар каф. мөдире, 2003 кә кадәр профессор-консультант. Хезмәтләре кичектергесез хирургиягә, перитонит патогенезына һәм аны дәвалауга карый. С. корсак ярысы ялкынсынуы барышындагы патогенетик механизмнарны өйрәнә; абдоминаль рецепторларның функцияләре үзгәрү динамикасын ачыклый, ашказаны ялкынсынуын селектив мукоэктомия алымы б-н хирургик дәвалау ысулын эшли һәм клиник кулланышка кертә. 1983–93 тә Респ-ка хирурглар җәмгыяте рәисе. Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Некоторые патогенетические механизмы перитонита в организме с неизменённой и изменённой иммунобиологической реактивностью. К., 1970; Использование гелий-неонового лазера в хирургии перитонита. К., 1989 (автордаш); Результаты хирургического лечения острого холецистопанкреатита // Вестн. хирургии. 1993. № 4.

*Әд.:* Богоявленский В.Ф. Профессор Ирек Алимзянович Салихов // Казан. мед. журн. 1997. № 3.

**САЛИ́ХОВ** Кев Миңнулла улы (3.11.1936, БАССРның Бәләбәй р-ны Красная Речка пос.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1976), ТР ФА академигы (1992), РФА академигы (2011), РФА мөхбир әгъзасы (1997), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1995). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1962 дән Караганда политехник ин-тында эшли. 1963–88 дә СССР ФА Себер бүлегенең Химик кинетика һәм яну ин-тында эшли (Новосибирск ш.), баш фәнни хезмәткәр (1986 дан), проф. (1981); бер үк вакытта, 1968–88 дә, Новосибирск ун-тында. 1988 дән РФА КГҮнең Физика-техника ин-ты директоры һәм химик физика бүлеге мөдире. Бер үк вакытта Казан ун-тының химик физика каф. мөдире (1989–2012), РФА КГҮ рәисе урынбасары (1991–2012), ТР ФА вице-президенты (1992 дән). Хезмәтләре химик физикага һәм радиоспектроскопиягә карый. С.ның химик реакцияләрдә магнит-спин эффектлары буенча хезмәтләре фәннең яңа юнәлеше — спин химиясенә нигез салуда һәм аны үстерүдә зур роль уйный. Ленин бүләге лауреаты (1986). Конденсатлашкан тирәлекләрдәге парамагнетик кисәкчәләр арасында бимолекуляр спин алмашуның заманча теориясен булдыра. ЭПРның импульслы спектроскопиясе теориясендә нигез булып торырлык нәтиҗәләр ала. Фотосинтетик системаларның реакция үзәгендә, кояш энергиясе ассимиляциясенең беренче стадияләрендә хасил була торган бүленмә корылмалар ЭПРның вакыты ачыкланган спектроскопиясе теориясен үстерә. Парамагнетик кисәкчәләр тыгызлыгының спинлы матрицасы өчен кинетик тигезләмәләр тәкъдим итә, аларда кисәкчәләрнең үзара тәэсир итешү өлкәсе аша диффузион үткәндәге бимолекуляр бәрелешләре исәпкә алына. Беренчеләрдән булып, үткәрүчән объектлар һәм диэлектрик югалтулары булган объектларның ЭПР-томографиясе алгоритмын эшли. С. житәкчелегендә кешенең тулы гәүдәсенә магнит-резонанслы томограф эшләнә (1997, РФ Сәламәтлек саклау министрлыгында сертификат ала һәм файдалануга тапшырыла). Халыкара «Applied Magnetic Resonance» ж-лын оештыручы һәм аның беренче мөхәррире (1990). Халыкара ЭПР җәмгыятенең вице-президенты (2001–03), *Е.К.Завойский исем. Халыкара бүләк* билгеләү буенча Халыкара ком-т рәисе

(1991–2003, 2005 тән), ТР Фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре фондының эксперт советы рәисе (1997–2002). Күптомлы Татар энциклопедиясенең Баш гыйльми мөхәрририяте әгъзасы, Татар энциклопедиясенең «Физика» бүлеге буенча гыйльми мөхәрририят рәисе (1992 дән). «Элементар физик-химик процессларның спин динамикасы» («Спиновая динамика элементарных физико-химических процессов»; 1974–97дә нәшер ителә) хезмәтләре циклы өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (1998). ЭПР һәм аны химиядә, биофизикада куллану теориясен үстергәне өчен Александр фон Гумбольдт исем. Халыкара фонд бүләге (Германия, 2001), Е.К.Завойский исем. Халыкара бүләк (2004) лауреаты. «Почёт билгесе», 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары; медальләр, ш.и. Халыкара ЭПР җәмгыятенең алтын медале, RIKEN ин-тының «Танылган галим» дипломы (Япония) б-н бүләкләнә. Казан шәһәренең мактаулы гражданы (2011).



К.М. Салихов.

Х е з м.: Электронное спиновое эхо и его применение. Новосиб., 1976 (автордаш); Спиновый обмен. Новосиб., 1977 (автордаш); Магнитные и спиновые эффекты в химических реакциях. Новосиб., 1978 (автордаш); Magnetic Isotope Effect in Radical Reactions. W.–N.Y., 1996; Quantum teleportation across a biological membrane by means of correlated spin pair dynamics in photosynthetic reaction centers // Appl. Magn. Reson. 2007. V. 31, № 1–2 (автордаш).

*Әд.:* Кев Минуллинович Салихов (к 70-летию со дня рождения) // Казан. физ.-техн. ин-т им. Е.К.Завойского. 2006: Ежегодник. К., 2007.

**САЛИ́ХОВ** Мидхәт Абдулла улы (19.9.1923, Чуаш Респ-касының Козловка р-ны Кармыш а. — 30.8.1994, Мәскәү), генерал-лейтенант (1985), Сов. Союзы Герое (10.1.1944). Подольск артиллерия уч-щесен (1942), М.В.Фрунзе исем. хәрби академияне (Мәскәү, 1948), СССР Кораллы Көчләре Генштабының К.Е.Ворошилов исем. Хәрби академиясен (Мәскәү, 1966) тәмамлый. 1942 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 676 нчы артиллерия полкында батарея командиры (38 нче армиянең 332 нче укчы дивизиясе). Воронеж, 2 нче Украина һәм 4 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Воронеж-Кастория (1943), Житомир-Бердичев (1943–44), Львов-Сандомир (1944) һәм Прага (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Днепр елгасын кичеп, Лютеж авылы (Украина ССР, Киев өлкәсенең Вышгород р-ны) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: 1943 нең 4 октябренә каршы төндә С. житәкчелегендәге батарея, дивизиянең бер өлешенә елга аша чыгарга булышып, дошманның җанлы көчләренә һәм техникасына сизелерлек зыян китерә. Сугыштан соң Мәскәүдә яши, СССР Кораллы Көчләре Генштабының К.Е.Ворошилов исем. Хәрби академиясендә эшли. 1993 тән отставкада. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткәне өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



М.А. Салихов.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**САЛИ́ХОВ** Мөхәммәдкасыйм Габделгалләм улы (1871, Казан губ., Казан өязе Чыршы а. — 1954), дин эшлеклесе, илаһият галиме. Апанай мәчете каршындагы мәдрәсәне тәмамлый, 1899 елдан шул ук мәчеттә имам-хатиб (1930 га кадәр) һәм үз исеме б-н аталган «Касыймия» мәдрәсәсендә мөдәррис (1918 гә кадәр). С. биредә җәдиди укыту ысулы кертә. Февр. рев-циясеннән соң, 1917 дә, Казанның Руханилар берлеге идарәсе рәисе. Илаһият гыйлеме турында хезмәтләр авторы. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Исторические мечети Казани. К., 2005.

**САЛИ́ХОВ** Радик Рим улы (10.4.1965, Арча р-ны Яңа Кенәр а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2006). ТР ФА академигы (2016; 2011 дән мөхбир әгъза). Казан ун-тының филол. ф-тын тәмамлаганнан соң (1989), ТР ФА Тел, әдәбият һәм тарих ин-тының тарих һәм мәдәният истәлекләре җыелмасы бүлегендә эшли. 1997 елдан ТР ФАнең Тарих ин-тында, яңа һәм иң яңа тарих бүлеге мөдире (2007–11), директор урынбасары (2011 дән). Хезмәтләре татар мәдәниятенең күренекле вәкилләре эшчәнлегенә, Татарстандагы истәлекләрне өйрәнү мәсьәләләренә, 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башы татар буржуазиясе тарихына карый. С. 19 йөз — 20 йөзләр чигендә Россиядә татар җәмгыяте эволюциясен, татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен өйрәнүгә зур өлеш кертә. Күптомлы «Иң борынгы чорлардан башлап татар тарихы» («История татар с древнейших времен»: в 7 т. К., 2002–15) авторларының берсе. Казанга нигез салыну вакытын, шәһәрнең барлыкка килү этапларын дәлилләгән һәм аның тарихи-мәдәни мирасына багышланган хезмәтләр циклы өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2008). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Татарская буржуазия Казани и национальные реформы второй половины XIX — начала XX вв. К., 2000; Участие татарского предпринимательства России в общественно-политических процессах второй половины XIX — начала XX вв. К., 2004; Исторические мечети Казани. К., 2005 (автордаш).

**САЛИ́ХОВ** Рәшит Абдулла улы (5.3.1930, Кыргызстан АССР, Тянь-Шань өлкәсе Кочкорка а.), философ, филос. фән. д-ры (1982). Мәскәү пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), урта мәктәптә эшли (Мәскәү). 1967–91 елларда РФАнең Философия ин-тында, 1991–97 дә РФ Милләтләр эшләре һәм федератив мөнәсәбәтләр министрлыгында бүлек башлыгы. Хезмәтләре милләтләр һәм милләтара мөнәсәбәтләр мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Проблема сочетания пролетарского интернационализма и патриотизма. М., 1971; Ленинская национальная политика КПСС и её фальсификаторы. М., 1982 (автордаш); Национальные процессы в СССР. М., 1987 (автордаш).

**САЛИ́ХОВ** Рәшит Мәгъсут улы (15.9.1954, Азнакай р-ны Буралы а.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005), ТРның атказ. машина төзүчесе (2004). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1978), Горький автомобиль з-дында эшли. 1979–85 елларда «КамАЗ» ҖБдә: инженер-технолог, участок башлыгы, агрегат з-ды цехында смена башлыгы. 1985–90 да партия эшендә. 1990 нан «АлАЗ» ЖБ» АҖдә: автоагрегат з-дында директор урынбасары (1990 нан), станоклар төзелеше з-дында директор (1992 дән), директор урынбасары (2002 дән). Дәүләт бүләге нефть һәм газ скважиналарын үзләштерү һәм ремонтлау өчен югары технологияле күтәрү агрегатлары (50 һәм 80 *т* йөк күтәрешле) эшләгәне һәм житештергәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.


**САЛИ́ХОВ** Рәшит Салих улы (21.7.1941, Тәкәнеш р-ны Көмешкүл а), табигый тирәлекне контрольдә тотуның космик чаралары өлкәсе белгече, техник фән. канд. 1964 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1965 тән Электромеханика фәнни-тикшеренү ин-тында (Истра ш., Мәскәү өлкәсе), лаб., бүлек башлыгы, ген. директор урынбасары, «Метеор-2», «Метеор-3» космик аппаратларының баш конструкторы урынбасары (1984–94), соңрак «Метеор-3», «Метеор-3М» космик комплекслары баш конструкторы, «Элкос» космик техника бүлеге директоры.

**САЛИ́ХОВ** Рим Гариф улы (15.9.1937, Мари АССРның Звенигово р-ны 106 нчы участогы — 24.8.2006, Алабуга ш.), әдәбият белгече, филол. фән. д-ры (1999), проф. (2001). Казан ун-тын тәмалаганнан соң (1963), Питрәч р-нының авыл мәктәпләрендә укыта, 1965–71 елларда «Коммунистик хезмәт өчен» Мамадыш район г-тасында эшли. 1974 тән Алабуга пед. ун-тында (1991–98 дә һәм 2005 тән татар филологиясе каф. мөдире). Хезмәтләре хәзерге заман татар әдәбиятына (стиль һәм жанр үзенчәлекләре, характер проблемалары, герой концепциясе, татар әдәби тәнкыйтенең теоретик һәм практик мәсьәләләре), татар әдәбияты тарихына, фольклорга багышлана.

Х е з м.: Г.Әпсәләмов геройлары дөньясы (анализ тәҗрибәсе). Алабуга, 2003; Әдәби Алабуга. Алабуга, 2005 (автордаш); Герой и эпоха (концепция героя в татарском литературоведении). К., 1999; Солнце рассеивает туманы (творчество Эдуарда Касимова). Алабуга, 2005 (автордаш).

*Әд.:* С а ф и н М. Иҗат бәхете // Мәйдан. 2002. № 5.

**САЛИ́ХОВ** Харис Салих улы (30.7.1927, Арча кантоны, хәзер Балтач р-ны Чутай а.), дин эшлеклесе. КПССның Горький югары партия мәктәбен (1962), Ислам динен кабул итүнең 1000 еллыгы исем. Казан югары мөселман мәдрәсәсен (1993) тәмамлый. Бөек Ватан су-



Х.С. Салихов.

гышында катнаша. 1951–54 елларда Эчке эшләр министрлыгының Мәскәү–Рязань тимер юлы идарәсендә (Мәскәү). 1954–58 дә КПССның Чепья райкомында пропаганда бүлеге мөдире урынбасары. 1962 дә Кама Тамагы р-ны башкарма ком-ты рәисе урынбасары. 1962 дән Казанда, КПССның Совет райкомы инструкторы. 1965 тән Совет, Вахитов р-ннары эчке эшләр идарәләре башлыгы урынбасары, милиция полковнигы. 1978–87 дә «Татнефтепроводстрой» трестында. 1993–97 дә ТР Мөселманнары Диния нәзарәтенең баш мөхтәсибәте сәркәтибе, нәзарәт рәисе урынбасары. 2005 тән «Хәтер» мәчете имам-хатибы. Ислам тарихы, А.С.Пушкин һәм Г.Тукай иҗатында Коръән үрнәкләрен яктырткан хезмәтләр авторы; А.С.Пушкинның «Подражания Корану» һ.б. шигырьләрен татар теленә тәрҗемә итә. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр; РФ Эчке эшләр министрлыгының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә (2007).

Х е з м.: Ислам тарихы вә нигезләре. К., 2000; А.Пушкин һәм Г.Тукай иҗатында Коръән аһәңнәре. К., 2001; А.Пушкин, Г.Тукай иҗатында Коръән вә бүгенге рухи тәрбиянең бер мәсьәләсе. К., 2008; Дин вә фән. Дөньякүләм дини һәм мәдәни этика нигезләре: Дәреслеккә ярдәмлек. К., 2012; Краткая история ислама. К., 1997; Религия и наука. Основы мировых религиозных и светских культур. Учеб. пособие. К., 2012.

*Әд.:* Х у җ и ә х м ә т о в Ә. Дин һәм гыйлемлелек // Мәгариф. 2009. № 6.

**САЛИ́ХОВ** Хафиз Миргаҗәм улы (5.9.1950, Сарман р-ны Әлмәт а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, физика-матем. фән. д-ры (2010), ТРның атказ. икътисадчысы (2005). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1974). 1974–89 елларда Казан югары хәрби инженерлар уч-щесендә инженер, лаб. башлыгы. 1989–94 тә «Хезмәт күрсәтү үзәге» пр-тиесе (Казан), 1994–98 дә ТР Тышкы икътисади багланышлар министрлыгы каршындагы (1997 дән — ТР МК каршындагы) Халыкара хезмәттәшлекне үстерү агентлыгы ген. директоры. 1998–2001 дә ТРның сәүдә һәм икътисади хезмәттәшлек министры. 2001–07 дә ТРның сәүдә һәм тышкы икътисади хезмәттәшлек министры. РФ Федераль Җыенының Дәүләт Думасы депутаты (2007 дән). Медальләр б-н бүләкләнә.

**САЛИ́ХОВ** Һарун Сәмигулла улы (15.8.1913, Казан — 21.10.1971, шунда ук), математик, физика-матем. фән. д-ры (1946), проф. (1948), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1960). 1935 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан авиация ин-тында эшли. 1937 дән Казан пед. ин-тында, физика-матем. ф-ты деканы (1941–43), алгебра һәм геом. каф. мөдире (1946–59), бер үк вакытта, 1946–71 дә, СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында, матем. секторы мөдире (1959 дан). Хезмәтләре дифференциаль тигезләмәләргә, якынча һәм санлы алымнарга, гамәли математикага карый. С. 1 нче тәртип аерым чыгарылмалы дифференциаль тигезләмәләрнең башлангыч Коши бирелмәләре һәм структуралары өчен кирәкле һәм җитәрлек шартлар табу турындагы «Коши–Ковалевская кире мәсьәләсе»нә аналитик чишелеш таба. Оптимальләштерү мәсьәләләрендә С. һәм аның шәкертләре эшләгән матем. программалаштыру алымнары Баулы, Ромашкино һ.б. нефть чыгару мәйданнарының проектларын төзүдә кулланыш таба. «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Вычисление рядов. М., 1955; Математический анализ: Функции, пределы, ряды, цепные дроби. М., 1961; Вычисление рядов и несобственных интегралов. К., 1973 (автордаш).

**САЛИ́ХОВ** Һибәтулла Сәетбаттал угылы (тәхәллүсләре Һибәтулла Салихбаттал, Һибәтулла Каргалый, Һибәтулла ишан) (1794, Оренбург губ. Түбән Чебенле а. — 1867, Оренбург губ. Каргалы бистәсе), шагыйрь, дин эшлеклесе. Мулла гаиләсеннән. Бабалары Оренбург губернасына Казан губернасының Чистай өязеннән күчеп килә. Каргалы мәдрәсәсендә белем ала; 1842 елдан шунда ук мөдәррис, бистә мәчетенең имам-хатибы була. Үзе исән чакта ике шигъри җыентыгы дөнья күрә: «Төхфәт әл-әүляд» («Балаларга бүләк»), «Мәҗмәг әл-әдәб» («Әдәпкә өйрәтү җыентыгы», 1856). Беренче китапта гарәп теле фонетикасы бирелә. Икенчесе дини-әдәп нәсыйхәтләреннән гыйбарәт: автор ялгыш адымнар ясаудан тыелырга, гадел булырга, дини-әхлакый кануннар буенча яшәргә өнди; үгет-нәсыйхәт сүзләрен тиешле хикәяләр б-н ныгыта (мәс., берсендә автор ахмак кешене үзеңә юлчы итеп алырга ярамаганлыгын күрсәтә; «Гаса кеби булып» дип башланган хикәясендә «таяк кебек сүзсез, сер саклаучы», «ялгызга юлдаш», «адашканга маяк», «сукырга ярдәмче» булырга, ягъни кешегә һәрвакыт ярдәм итәргә өнди). Автор күптөрле жанрларда иҗат итә: мәдхия, мәрсия, газәл, мәсәл, шигъри хикәят һ.б.; аларның бер өлеше Р.Фәхретдиннең «Асар» (Оренбург, 1908) китабында урын алган. «Тәндә җаным» («Диване Ризаи» җыентыгына кергән, 1860) лирик шигырендә С. суфичылык вәгазьләрендә дөньяның фанилыгы, кылган гамәлләрнең файдасызлыгы турында бәян итә (1906 да Тукай бу шигырьгә «Мөритләр каберстаныннан бер аваз» исемле пародия яза). Кайбер мәгълүматлар буенча С. — «Дөррә әл-кәлям» («Сөйләм энҗеләре», 1856) китабы авторы. С. шигырьләре лирик-фәлсәфи афористик стиль, оригиналь чагыштырулар һәм метафораларның күплеге б-н аерылып тора. Аның әсәрләрендә чит тел сүзләре, гарәп яки фарсы телендә язылган шигъри юллар очрый; бер үк вакытта авторның сөйләм телен куллануга омтылышы да сизелә.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. Т. 2; Г а й н у л л и н М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**САЛИ́ХОВ** Энмарк Шакир улы (12.9.1934, Үзбәкстан ССР, Ташкент), композитор, җәмәгать эшлеклесе, Үзбәкстан ССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1984). 1963 елда Ташкент консерваториясен композиция буенча (Б.И.Зейдман классы) тәмамлый, 1968–73 елларда шунда укыта. 1964–65 тә Үзбәкстан ССРның Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт ком-ты эстрада-симф. оркестрының сәнгать җитәкчесе. 1969–70 тә Үзбәк филармониясе эстрада оркестрының сәнгать җитәкчесе, 1973–76 да «Үзбәкконцерт» һәм «Үзбәкдәүләтэстрада»ның сәнгать җитәкчесе. 1971 дән Үзбәкстан ССР Композиторлар берлеге идарәсенең җаваплы сәркәтибе, 1975–81 дә — рәисе. 1981 дән Үзбәкстан ССР Мәдәният министрлыгының муз. театрлар идарәсе башлыгы. 1968 дән башлап, СССРда танылган джаз фестивальләрен оештыра һәм дирижёр буларак үзе дә катнаша. 1978–88 дә Үзбәкстан ССР ЮС депутаты. Үзбәкстанның Ленин комсомолы бүләге лауреаты (1970).

Төп әсәрләре: Үзбәкстан ССРның 40 еллыгына багышланган симфония (1963); «Генерал Сабир Рәхимов истәлегенә» (1960), «Эрҗигитов истәлегенә» (1975) симф. поэмалары; кыллы квартетлар (1963, 1966); соната (1965); «Ялкынлы җыр» («Пламенная песня», 1971) балеты; «Хуҗа Насретдин» (1981) опереттасы; «Айгөл бүләкләре» («Подарки феи Ойгуль», 1976), «Гаҗәеп дойра» («Чудесная дойра», 1980) мюзикллары. Рус (башлыча, О.Гаджикасыймов сүзләренә) һәм үзбәк телләрендә В.Ободзинский, Л.Лещенко, «Ялла» үзбәк ансамбле һ.б. башкарган 50 дән артык җыр; Үзбәкстан һәм Россия киностудияләрендә (башлыча, реж. Л.Фәйзиев тарафыннан) төшерелгән «Күз ачылу» («Прозрение», 1964), «Шомланулар чоры» («Возраст тревог», 1966), «Билгеләнмәгән матч» («Некалендарный матч», 1972), «Алтын сарык йоны» («Золотое руно», 1981), «XX йөз динозаврлары» («Динозавры XX века», 1990), «Яр» (1991), «Барысы өчен дә түләргә кирәк» («За всё надо платить», 1993), «Алпамыш» (2000) фильмнарына, телефильмнарга һәм үзбәк театрлары спектакльләренә музыка авторы.

**САЛИ́ХОВА** Ләйлә Леонард кызы (21.7.1965, Казан), педагог, математик, физ.-матем. фән. канд. (1993), пед. фән. д-ры (2009). Казан ун-тын тәмамлый (1987). 1990 елдан Татар гуманитар-пед. ин-тының алгебра кафедрасында укыта. 2011 дән Казан ун-тында, 2013 тән филологиядә матем. лингвистика һәм мәгълүмат системалары каф. мөдире. Хезмәтләре фәннәр чит телдә укытыла торган мәктәпләрдә математика укыту методикасына, математиканы билингваль укыту методикасына карый.

Х е з м.: Теория и практика развития школ с билингвальным обучением. К., 2004; Билингвизм и мышление: о взаимосвязи мышления и речи в контексте билингвального изучения математики. Saarbruken, 2012.

**САЛИ́ХОВА** Наилә Рөстәм кызы (25.6.1962, Казан), психолог, психол. фән. д-ры (2011). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1985). 1989 елдан Казан ун-тында, гомуми психол. каф. профессоры (2011). Хезмәтләре шәхеснең толерантлык психологиясенә, шәхес кыйммәтләре контекстында мәгънәлелек мәсьәләләренә, субъектның тормыш эшчәнлеген-

дә кыйммәт-мәгънә көйләнешен өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Языковые модели. К., 2009; Уровневый подход к переживанию // Бехтеревские психологические традиции в Казанском университете. К., 2010; Психологические механизмы и технологии трансформации языковых моделей мира. К., 2014; Смысловая регуляция психических состояний: психологические механизмы и технологии. К., 2015 (автордаш).

**САЛИ́ХОВА** Рәйсә Сәмигулла кызы (16.10.1910, Казан — 31.10.1985, Варшава, Польша), педагог, пионерлар хәрәкәте эшлеклесе. Ш.Ә.*Таһировның* оныгы. Татар пед. техникумын (1926), В.И.Ленин исем. Мәскәү пед. ин-тын (1935) тәмамлый. 1924 елда Казанның Яңа Татар бистәсендә ТАССРда беренче татар пионерлар отрядын оештыра, 1928 гә кадәр аның җитәкчесе була. Бер үк вакытта, 1926–29 да, Иске Татар бистәсе һәм Яңа Татар бистәсен үз эченә алган Түбән Шәһәр р-нында пионер отрядларының район бюросы рәисе. 1920 елларның 2 нче яртысында С. һәм И.И.*Малкин* Респ-ка пионерлар оешмасының җитәкчесе булалар. 1936–45 тә С. Казан мәктәпләрендә укытучы һәм өлкән пионервожатый булып эшли. 1945–52 дә Казан пед. уч-щесендә пионерлар эше бүлеге мөдире, бер үк вакытта пионервожатыйлар әзерләү буенча респ-ка мәктәбендә директор, Казан халык мәгарифе шәһәр бүлегенең пионерлар эше буенча инспекторы, ВЛКСМ өлкә ком-ты һәм В.И.Ленин исем. Пионерлар оешмасы респ-ка советы әгъзасы. 1952–60 та Казан мәктәпләрендә биол. укыта. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* М а л к и н И.И., Н о с о в С.С., Я р у л л и н Ш.Н. Марш пионерии Татарстана. К., 1973; М а л к и н И.И. Первые галстуки. К., 1984.

**САЛИ́ХОВА** Роза Гавис кызы (20.10.1948, Актаныш р-ны Усы а.), драма актрисасы, ТРның халык артисты (1998), БРның атказ. артисты (1997). 1969 елда, Әлмәт музыка уч-ще студенты буларак, Әлмәт татар драма театрына муз.-драматик спектакльләрдә яшь героиня рольләрен башкару өчен чакырып алына. Җырга-моңга табигый сәләте, мөлаемлыгы, тышкы матурлыгы С.га Асия («Үр менгәндә», Т.Закиров), Зәйнәп («Яшьлек чәчәк атканда», И.Кәтиев), Гөлсем («Бишбүләк», Т.Гыйззәт), Гөлчәчәк («Эх, Уфа кызлары!», И.Абдуллин), Гыйлемия («Минем җинаятем», Ю.Әминев), Тәнзилә («Тальян моңы», Ш.Бикчурин), Зөһрә («Их сез, егетләр!», Ф.Садриев), Шәмсекамәр (М.Әблиевнең шул исем. әсәре буенча), Дилбәр («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин), Наилә («Без уникe кыз идек», А.Гыйләҗев), Мирандолина («Тылсымлы кыз», К.Гольдони) кебек нечкә психологизм б-н сугарылган лирик рольләр башкарырга мөмкинлек тудыра.

**САЛИ́ХОВА** Роза Галләм кызы (24.9.1944, Свердловск өлкәсенең Түбән Тагил ш. — 2007, Мәскәү), спортчы (волейбол), СССРның атказ. спорт остасы (1969). Мәскәү өлкә пед. ин-тын тәмамлый (1971). Спорт б-н 1960 елда Түбән Тагилда шөгыльләнә башлый (тренеры — А.Кильчевский). 1964–69 да «Труд» (Свердловск), 1969 дан «Динамо» (Мәскәү) командаларында уйный. 1966–75 тә СССР җыелма командасы әгъзасы. СССР (1970–73, 1975, 1977), Европа (1967, 1971), дөнья (1970), Олимпия уеннары (1968, 1972) чемпионы; дөнья чемпионатында көмеш медаль ала (1974); Европа чемпионнары Кубогы (1969–72), дөнья Кубогы (1973) иясе. 1969 дан Мәскәүдә, тренер-укытучы булып эшли. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**САЛИ́ХОВА** Фирдәвес Вәли кызы (29.12.1933, Тәтеш р-ны Олы Тархан а. — 10.8.2014, Казан), географ, геогр. фән. канд. (1980). 1955 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1959 дан Казан төзүче инженерлар ин-тында, 1969–2010 да — Казан пед. ин-тында (2005 тән Татар гуманитар-пед. ун-ты). 1971–74 тә Алжирда: СССР илчелеге каршындагы урта мәктәптә, Алжир нефть ин-тында (Бумердес ш.) укыта. 1985–86 да Әфганстанда: Кабул пед. ин-тының геогр. каф. мөдире. Хезмәтләре Урта Идел буе, Казан үзән карстлары барлыкка килүнең теоретик аспектларына һәм динамикасын өйрәнүгә карый. Идел буе болгар-татар цивилизациясе формалашу буенча геогр. тикшеренүләр үткәрә.

Х е з м.: География Афганистана. Кабул, 1986 (автордаш); География Кабула. Кабул, 1986 (автордаш); Башня Сююмбике и истоки цивилизации булгаро-татар. К., 2001.

**САЛКЫ́Н АЛА́Н** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 28 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Ирнә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 65 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Клуб, китапханә. 1924 тә Урта Кәшер һәм Яңа Имән авылларыннан күченүчеләр нигез сала. Оештырылган көненнән ТАССРның Чаллы кантоны Сарман волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1966 ның 3 гыйнварыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 325, 1938 дә — 473, 1949 да — 600, 1958 дә — 486, 1970 тә — 348, 1979 да — 267, 1989 да — 110, 2002 дә — 92 кеше.

**САЛКЫ́Н ЧИШМӘ́** посёлогы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 37 *км* төньяк-көнбатыштарак, Күклек елгасы буенда. 2010 елда 53 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1680 нән Салкын Чишмә Пүчинкәсе буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Зиняр (Зинери) исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 368,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Чиркәс волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1905 тә — 156, 1920 дә — 159, 1926 да — 173, 1938 дә — 418, 1958 дә — 223, 1970 тә — 114, 1979 да — 70, 1989 да — 84, 2002 дә — 83 кеше.

**САЛКЫ́Н ЧИШМӘ́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 40 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Урсалы елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 47 кеше (татарлар) яши. 1929 да Урсалыбаш авылыннан күченүчеләр (алар арасында Сов. Союзы Герое М.Ә.*Әхмәдуллин* да була) нигез сала. Оештырылган көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Әлки волостенда. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1938 дә — 256, 1949 да — 226, 1958 дә — 296, 1970 тә — 157, 1979 да — 99, 1989 да — 22, 2002 дә — 33 кеше.



Роза Гавис кызы Салихова.

**САЛКЫ́Н ЧИШМӘ́** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 30 *км* көньяк-көнбатыштарак, Батрас елгасы бассейнында урнашкан. Даими яшәүчеләр юк. 1927 елда Олы Батрас авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оештырылган көненнән ТАССРның Чаллы кантоны Зәй волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1938 дә — 152, 1949 да — 109, 1958 дә — 92, 1970 тә — 46, 1979 да — 21, 1989 да — 10 кеше (руслар).

**САЛКЫ́Н ЧИШМӘ́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 12 *км* көньяк-көнбатыштарак, Оштырма елгасы буенда. 2010 елда 68 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — иткә терлек асрау. Клуб. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында На горе у Студёного Ключа, Алыш-Аул, Алеш-Гурт исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 353,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 13 ир-ат; 1859 да — 110, 1897 дә — 149, 1908 дә — 142, 1920 дә — 166, 1938 дә — 208, 1949 да — 149, 1958 дә — 145, 1970 тә — 163, 1979 да — 159, 1989 да — 94, 2002 дә — 79 кеше.

**САЛКЫ́Н ЧИШМӘ́** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 12 *км* төньяктарак, Үшнә елгасы буенда. 2010 елда 178 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. Мәчет. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Арча кантоны Питрәч волостенда. 1930 ның

10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1926 да — 299, 1949 да — 276, 1958 дә — 258, 1970 тә — 272, 1979 да — 290, 1989 да — 236, 2002 дә — 179 кеше.

**САЛКЫ́Н ЧИШМӘ́** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 23 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ютазы елгасы буенда. 2010 елда 120 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1920 еллар башында нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Бәйрәкә волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1922 дә — 255, 1926 да — 287, 1938 дә — 292, 1949 да — 273, 1958 дә — 269, 1970 тә — 292, 1979 да — 222, 1989 да — 136, 2002 дә — 116 кеше.

**САЛКЫ́Н ЧИШМӘ́** посёлогы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 6 *км* көньяктарак, Мәҗын елгасы буенда. 2010 елда 173 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 70%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1932 дә нигез салына. Оештырылган көненнән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1938 дә — 120, 1958 дә — 260, 1970 тә — 416, 1979 да — 365, 1989 да — 207, 2002 дә — 184 кеше.

**САЛКЫНСУ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Минзәлә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 14,3 *км*, бассейнының мәйданы 74,2 *км*$^2$. Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгы буйлап ага. Елга башы урман массивында, Әлмәт р-ны Бикәсаз авылыннан 2,5 *км* көнбатыштарак, тамагы Сарман р-ны Ләшәү-Тамак авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 270 *м*, тамагыныкы — 150 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. С.ның 0,4 тән 5,3 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, өчтән ике өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 77 *мм*, ташу агымы катламы 50 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче унконлегендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,07 *м*$^3$*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан артык. С. бассейнында суның гомуми күләме 0,4 млн. *м*$^3$ булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**САЛМА́**, кабырчык рәвешендәге камыр ризыгы. С. бодай, карабодай, ясмык яисә борчак оныннан әзерләнә. Әзер камырны өлешләргә бүлеп, 1–1,5 *см* калынлыкта итеп баусыман тәгәрәткәч, Әстерхан чикләвеге зурлыгында кисәкләргә киселә, аларны колак яфрагы формасына китереп киптерәләр. Татарларда С., гадәттә, шулпада кабартып бирелә, аңа катык өстәп, вак итеп туралган яшел тәмләткечләр салына. Ш.у., бәрәңгеле, борчаклы, ясмыклы ашлар әзерләү өчен, суган һәм кишер б-н дә кулланыла.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в Ю.Ә. Татар халык ашлары. К., 1999; Татарская кухня. К., 1985.

**САЛМА́КОВ** Константин Михайлович (16.9.1929, Казан), вет. микробиологы, вет. фән. д-ры (1980), проф. (1984), РСФСРның атказ. вет. табибе (1980), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1995). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), Казан респ-ка вет. лаб-ясендә табиб-эпизоотолог. 1953–84 елларда Казан вет. ин-тында: өлкән фәнни хезмәткәр, бруцеллёз лаб-ясе мөдире. 1984 тән Хайваннарның токсикологик һәм радиацион куркынычсызлыгы буенча федераль үзәкнең (2004 кә кадәр — Бөтенроссия вет. фәнни-тикшерену ин-ты) бактерияле йогышлы авырулар лаб-ясе мөдире. Фәнни тикшеренүләре бруцеллёз вакытындагы аллергияне, авыру китереп чыгаручының үзгәрүчәнлеген өйрәнү өлкәсенә карый. Бруцеллалар штаммы 82 дән бруцеллёзга каршы вакцина уйлап таба (1988 дә Россия, Казакъстан, Грузия һ.б. терр-яләрдә гамәлгә кертелә). Мөгезле эре терлекләрдә бруцеллёзга диагноз кую методикасын камилләштерә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Изучение антигенных и иммуногенных свойств живых и убитых бруцеллёзных вакцин // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1970. Т. 107; Испытание вакцины из слабоагглютиногенного штамма бруцелл 82 на крупном рогатом скоте // шунда ук. 83–87 б.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**САЛМА́Н** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Актай елгасының (Кама елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 25,3 *км*, бассейнының мәйданы 199,8 *км*$^2$. Идел аръягы түбәнлеге буйлап, Әлки р-нында ага. Елга башы Абдул Салманы авылы чигендә, тамагы Демидовка авылыннан 1 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 79 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. С.ның кушылдыгы — Нохрат елгасы (14,1 *км*) — уң кушылдык. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,21 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 81 *мм*, ташу агымы катламы 72 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче унконлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,005 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. С. басейнында суының күләме 0,6 млн. *м*$^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**САЛМА́Н** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 12 *км* төньяк-көнбатыштарак, Салман елгасы буенда. 2010 елда 212 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 49%, руслар — 48%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз башына кадәр нигез салына; 1939 га кадәрге исеме — Церковные Салманы. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Спас чиркәве (1795 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1881 дә ачыла), 2 җил тегермәне, 1 казна шәраб һәм 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 846 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Базарлы Матак волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас, 1935 нең 25 гыйнварыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 185 ир-ат; 1859 да — 418, 1908 дә — 674, 1920 дә — 665, 1926 да — 359, 1938 дә — 299, 1949 да — 252, 1958 дә — 285, 1970 тә — 345, 1979 да — 290, 1989 да — 213, 2002 дә — 222 кеше.

**САЛМА́НОВКА** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кылна елгасы буенда. 2010 елда 27 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Тулы булмаган урта мәктәп. 1640 елларда Тайба исемле татар авылы буларак нигезләнә. 1728 дә авыл тирәсендәге җирләрне прапорщик Фёдор Салманов сатып ала, һәм авылның исеме С. булып китә. 19 йөзнең 2 нче яртысындагы чыганакларда Глинки (җирле алпавытлар фамилиясеннән алынган) исеме б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү, чиркәү-приход мәктәбе (1899 да ачыла), 3 сәүдә-сәнәгать йорты эшли.Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 274 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 383, 1897 дә — 445, 1913 тә — 193, 1920 дә — 209, 1926 да — 238, 1938 дә — 256, 1949 да — 184, 1958 дә — 165, 1970 тә — 113, 1979 да — 66, 1989 да — 45, 2002 дә — 43 кеше.

**САЛМАЧЫ́** авылы, Казан шәһәренең Идел буе р-ны карамагында, Казан тимер юл станциясеннән 13 *км* көнчыгыштарак, Нокса елгасы буенда. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, бакчачылык. Казылык, сыр җитештерү, икмәк пешерү, җиләк-җимеш кайнату цехлары. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, чиркәү. 1565–67 еллардан билгеле. 16 йөз ахырыннан Казан Спас Преображение монастыре карамагында. 1763 тә халкы — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, яшелчәчелек, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.да земство мәктәбе (1881 дә ачы-

ла), 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2824,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Воскресенск волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенск, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән Питрәч р-нында. 2001 нең 24 маеннан Казанның Идел буе р-нына керә. Халык саны: 1782 дә — 228 ир-ат; 1859 да — 972, 1897 дә — 1115, 1908 дә — 1317, 1920 дә — 1496, 1926 да — 1608, 1949 да — 1089, 1958 дә — 956, 1970 тә — 868, 1979 да — 856, 1989 да — 1096 кеше (ш.и. руслар — 69%, татарлар — 28%).

**САЛТА́У-МАЯ́К КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.). Дон буе, Азов яны һәм Түбән Идел буе элгәреге урта гасырларга (якынча 8–10 йөзләр) карый. 1900 елда Харьков өлкәсенең Югары Салтау авылы янында табылган каберлек, 1890 да Тихая Сосна елгасы (Воронеж өлкәсе) тирәсендә ачылган Маяк шәһәрлеге һәм каберлегенә нисбәтле шулай атала. С.-м.к. истәлекләрен өйрәнү 19 йөз ахыры — 20 йөз башыннан алып барыла (М.И.Артамонов, И.И.Ляпушкин, С.А.Плетнёва h.б.). М.И.Артамонов аның мөстәкыйль культура сыйфатында аерып чыгара, терр. һәм хронологик чикләрен билгели. С.-м.к. хәзәрләр, болгарлар, аланнар һәм Хәзәр каганлыгы терр-ясендә яшәгән башка халыклардан калган дип санала. Халкы игенчелек, аучылык, төрле һөнәрләр, сәүдә, ш.у. урман-дала һәм далаларда күчмә терлекчелек б-н шөгыльләнә; авылларда һәм шәһәрләрдә (Фанагория, Итил, Саркел h.б.) яши, ак таштан ныгытмалар кору осталыгына ия була. С.-м.к.на караган терр-ядә шәһәр-кальгалар, ярлардагы борыннарда таш диварлы замоклар, туфрак валлар б-н әйләндереп алынган торулыклар калдыклары, күчмә туктаулыклар табыла. Тораклар күбесенчә җир өстендә, таш диварлы яисә үреп, балчык сылап эшләнгәннәр, ш.у. турыпочмаклы ярымземлянкалар һәм юрта рәвешендәге түгәрәк тору урыннары да очрый. С.-м.к.на караган каберлекләрнең берничә төре билгеләнә: катакомбалы (калкулык сыртларыннан аларга таба җир асты юллары — дромослар илтә); чокырлы (мәетне урнаштырып һәм яндырып); курганлы. Мәетне урнаштыру йоласы һәм бергә күмелгән әйберләр җыелмасы буенча үзенчәлекле каберлекләр дә очрый. Каберләрдә хезмәт кораллары (авыр төрән калаклары, ураклар, кәкре чалгылар, тегермән ташлары, пычаклар; кувшиннар, чүлмәкләр, хумнар h.б., сугыш кораллары (кылычлар h.б.ш.), дирбияләр (өзәңгеләр h.б.), ш.у. кием детальләре (бил каешы җыелмалары, асылмалар h.б.) һәм бизәнү әйберләре табыла. Татарстан терр-ясендә С.-м.к. истәлекләре б-н охшашлык *Болгар культурасы* истәлекләренең кайберләренә хас (к. *Олы Тархан каберлеге, Танкеевка каберлеге*).



Олы Тархан каберлегеннән табылган әйберләр.
1. Алкалар, йөзекләр h.б. Төсле металл;
2. Балчык чүлмәкләр һәм кувшиннар.

*Әд.:* Л я п у ш к и н И.И. Памятники салтово-маяцкой культуры в бассейне Дона // Материалы и исслед. по археологии СССР. 1958. № 62; А р т а м о н о в М.И. История хазар. Л., 1962; Г е н и н г В.Ф., Х а л и к о в А.Х. Ранние болгары на Волге. М., 1964; К а з а к о в Е.П. Культура ранней Волжской Болгарии. М., 1992.

**САЛТЫГА́Н** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 10 *км* көнбатыштарак, Карамалы елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 45 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. 1647–65 еллардан билгеле. Риваятьләргә караганда, Олы Кариле авылыннан күченүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Другие Большие Кляри, Кляри Другие, Большое Салтыганово исемнәре б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1853 тә төзелә), мәктәп, җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 660,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Богородский волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 83 ир-ат; 1859 да — 297, 1884 тә — 382, 1897 дә — 505, 1908 дә — 600, 1920 дә — 596, 1926 да — 383, 1938 дә — 430, 1949 да — 442, 1958 дә — 372, 1970 тә — 279, 1979 да — 212, 1989 да — 131, 2002 дә — 81 кеше. С. тирәсендә 14 йөз эпиграфик истәлекләр — кабер ташлары саклана.

**САЛТЫГА́Н** (Ышналыбаш) авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ышналы елгасы буенда. 2010 елда 241 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 17 йөз ахырына кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Мамадыш Верхней Шеланги Салтыганово, Шаланбаш, Мамадыш-Салтыганова исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 3 җил һәм 2 су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 985 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ульянково волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 104 ир-ат; 1859 да — 486, 1897 дә — 807, 1908 дә — 988, 1920 дә — 973, 1926 да — 606, 1938 дә — 679, 1949 да — 516, 1958 дә — 364, 1970 тә — 438, 1979 да — 380, 1989 да — 288, 2002 дә — 265 кеше.

**САЛТЫ́К-ЕРЫКЛЫ́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 22 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кәркәүч елгасы буенда. 2010 елда 96 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Клуб. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Салтык Сарыклы Елга, Татар Шонбашы исемнәре б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 587,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Лыябаш-Келәүш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 30 ир-ат; 1859 да — 299, 1897 дә — 541, 1908 дә — 572, 1920 дә — 486, 1926 да — 491, 1949 да — 360, 1958 дә — 215, 1970 тә — 180, 1979 да — 166, 1989 да — 146, 2002 дә — 114 кеше.

**САЛТЫКО́В** Алексей Петрович (1650 тирәсе — 1726 тирәсе, С.-Петербург), дәүләт эшлеклесе, бояр (1682), статский советник (1724). 1662 елдан дәүләт хезмәтендә.

1676–78, 1687–89 да Әстерхан, 1684–85 тә Киев воеводасы. 1682–84 тә Юлбасарлык, 1685–86, 1699–1707 дә Мәскәү мәхкәмә, 1711–13 тә Азык-төлек приказлары башлыгы. 1698–99 да Рязань полкы командиры. 1701 дә Якын канцелярия әгъзасы. 1713–16 да Мәскәү, 1719–24 тә Казан губернаторы. С. дәверендә Казан губернасы 5 провинциягә (к. *Провинцияләр*) бүленә (1719–20), Казанда пумпа з-ды барлыкка килә (1719), төбәктә җан башыннан салым кертелә (1724), казна постау мануфактурасы сәүдәгәр И.А.Михляевка тапшырыла (1724). 1719–22 дә губерна терр-ясендә 1 нче ревизия үткәрүгә булышлык итә, Пётр I нең Иранга яулары вакытында (1722–23) кораблар төзүдә, азык-төлек әзерләүдә катнаша. 1722–23 тә митрополит Тихон III б-н Идел буенда рус булмаган халыкларны христианлаштыруда катнаша, Казанда Архиерей йорты кирәк-яракларына акчалата ярдәм күрсәтә. 1721–22 дә Казан сарай мәхкәмәсе президенты. 1724 тән С.-Петербургта яши.

*Әд.:* Пупарев А.Г. Казанские губернаторы. К., 1856; Дворянские роды Российской империи. СПб., 1995. Т. 2; Серов Д.О. Администрация Петра I. М., 2007.

*Е.Б.Долгов.*

**САЛТЫКО́В** Михаил Михайлович (? — 1671, Кострома шәһәрендә җирләнә), дәүләт эшлеклесе, окольничий (1635), бояр (1641). «*Болгавыр заман*» дәверендә 2 нче ополчениедә катнаша (1611–12). Патша Михаил Фёдоровичның анасы б-н туганлык мөнәсәбәтләрендә булу сәбәпле, патша сараенда йогынтылы кеше була. 1616 елда патша б-н Д.Г.Хлопованың туйлары булмый калуның төп сәбәпчесе. Ул киленнең туганнарын кияүгә «авыру» кыз бирергә теләүләрендә гаепли. 1623 тә ялган ачыклана. Патриарх Филарет кушуы буенча С. сөргенгә җибәрелә, мал-мөлкәте тартып алына. 1633 тә, Филарет үлгәннән соң, аклана. Озак вакыт сарайда хезмәт итә. 1653–56 да Казанда 1 нче (баш) воевода. 1654 тә, үләт чире эпидемиясе вакытында, С. кушуы буенча Седмиозёрный Смоленск Мәрьям Ана иконасын тотып бару оештырыла.

*Е.В.Липаков.*

**САЛТЫКО́В** Пётр Самойлович (? — 1720 тирәсе), дәүләт эшлеклесе, бояр (1691). 1676 елдан Мәскәүдә дәүләт хезмәтендә. 1691 дән Смоленск воеводасы; 1704–06 да шәһәрне шведлар явыннан саклауда катнаша; 1711–13 тә Смоленск губернаторы, 1713–19 да Казан губернаторы. С. заманында идарәнең төгәлрәк булган системасы барлыкка килә: вице-губернатор билгеләнә, ландратлар (киңәшчеләр) советы оештырыла, Түбән Новгород (1714–17) һәм Әстерхан (1717) губерналары аерып чыгарыла. С. халыкның икътисади хәлен тотрыкландыру өчен төрле чаралар күрә, казнага салымнарны һәм җыелмаларны тиешле күләмдә генә түли, дәүләт керемен халык тормышына зыян китерү бәрабәренә арттыруга юл куймый. Россия армиясе өчен рекрутлар җыю, калмыклардан атлар сатып алу, кораблар төзү өчен агач хәзерләү һәм аны төяп җибәрү, С.-Петербургка эшчеләр озату, 1715–1718 дә йорт башыннан халык исәбен алу б-н шөгыльләнә; Идел буендагы рус булмаган халыкларны христианлаштыруга булышлык итә. Пётр I нең 1713 һәм 1715 тәге фәрманнары нигезендә чукынмаган татар морзаларының 560 утарын тартып ала, 4 меңгә якын крепостной крәстиянне сарай крәстияннәре катлавына күчерә. Казан постау мануфактурасы ачылуга (1714), Казан адмиралтействосы оештырылуга һәм төбәктә лашманлык йөкләмәсе кертелүгә булышлык итә (1718).

*Әд.:* к. А.П.*Салтыков* мәкаләсе.

*Е.Б.Долгов.*

**САЛТЫКО́ВКА** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 8 *км* көньяктарак, Туйма елгасы буенда. 2010 елда 3 кеше (руслар) яши. 1781 дә Тихие Горы авылыннан (хәзер Менделеев шәһәренә керә) күченүчеләр нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек экономик) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1879 елгы мәгълүматларга караганда, С.да ашлык саклау-сату кибете була. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 406,6 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1795 тә — 28 ир-ат; 1836 да — 109, 1859 да — 123, 1887 дә — 155, 1905 тә — 150, 1920 дә — 183, 1926 да — 197, 1938 дә — 172, 1949 да — 160, 1958 дә — 119, 1970 тә — 31, 1979 да — 18, 1989 да — 8, 2002 дә — 12 кеше.

**САЛЫ́М ДЕКЛАРА́ЦИЯСЕ** (лат. declaratio — белдерү), салым түләүченең агымдагы чорда алган керемнәре һәм тоткан чыгымнары, керем чыганаклары, салым ташламалары һәм салым исәпләүгә, салым түләүгә бәйле башка мәгълүматлар турында язмача белдерүе. Салымның декларация ысулы (С.д.) шәхси керемнәр үсүгә бәйле рәвештә кулланыла башлый. С.д. салым күләмнәрен билгеләү өчен гражданнарның керемнәре күләмен һәм башка мәҗбүри түләүләр алу һәм түләү срокларын билгеләүче төп финанс документларыннан берсе булып тора. С.д.ндә күрсәтелергә тиешле керемнәр составына төп эш (уку) урынында алган керемнәр; фән, әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен иҗат иткән, бастырып чыгарган, башкарган һәм башкача файдаланган өчен авторлык түләүләре, ш.у. ачышлар, уйлап табулар өчен түләүләр рәвешендә ала торган суммалар; чит дәүләтләрдән яисә чит дәүләтләрдә эшмәкәрлек б-н шөгыльләнүдән алынган керемнәр керә. С.д. һәм гамәлдәге салым нормалары нигезендә түләнергә тиешле салым күләменә контроль тормышка ашырыла. С.д. билгеләнгән формадагы бланкларда салым түләүче исәптә торган салым органына тапшырыла. 2001 елдан башлап, төрле чыганаклардан керемнәр алучы (күпме булуына карамастан), эшмәкәрлек б-н шөгыльләнүче һәм башка керемнәре булган гражданнар, календарь ел тәмамлануга, даими яшәү урыннарындагы салым органнарына салым чоры дәвамында фактта алган керемнәре һәм шул керемнәрне алуга тоткан чыгымнары турында декларация тапшырырга бурычлы. Узган календарь елда төп эш (уку) урынында хезмәт вазифаларын башкарудан гына керем алган физик затлар, хәтта ел дәвамында төп эш урыннарын алыштырсалар да, керемнәре турында декларация тапшырмыйлар.

*Әд.:* Финансово-кредитный словарь. М., 1986. Т. 2; Экономика, право, финансы: Бюджет государства и информационные технологии. Термины и определения. М., 1995; Черник Д.Г., Починок А.П., Морозов В.П. Основы налоговой системы. М., 1998.

*Н.З.Капкаева.*

**САЛЫ́М ИНСПЕ́КЦИЯСЕ**, дәүләт органы. СССР МСның 1990 ел 24 гыйнвар карары нигезендә ТАССР (1992 дән ТР) Дәүләт салым инспекциясе буларак оештырыла, РФ Президентының 1998 ел 23 декабрь Указы б-н РФ Салымнар һәм җыемнар министрлыгының Татарстан идарәсе итеп үзгәртелә. Салымнар турындагы законнарның үтәлешен, билгеләнгән салымнар һ.б. мәҗбүри түләүләрнең дөрес исәпләнүен, аларның тулысынча һәм вакытында тиешле бюджетка күчерелүен контрольдә тота; 34 шәһәр, район һәм районара С.и.н үз эченә ала. РФнең Салымнар һәм җыемнар министрлыгына (1991 гә кадәр — СССР Финанс министрлыгы каршындагы Баш дәүләт салым хезмәтенә, 1991–98 дә — РФнең Дәүләт салым инспекциясенә) буйсына.

*Е.Б.Долгов.*

**САЛЫ́М ПОЛИ́ЦИЯСЕ**, дәүләт органы. Татарстанда РФ Президентының 1992 ел 18 март Указы нигезендә ТР Дәүләт салым инспекциясе каршындагы ТР Салым тикшерүләре идарәсе буларак оештырыла, РФнең 1993 ел 15 июль Законы б-н ТР Салым полициясе департаменты, РФнең 1995 ел 17 декабрь Федераль законы б-н РФ Федераль салым полициясе хезмәтенең ТР буенча идарәсе, РФ Президентының 2003 ел 11 март Указы б-н ТР Эчке эшләр министрлыгының Салым җинаятьләре буенча идарәсе итеп үзгәртелә. Салым җинаятьләрен ачу, булдырмау һәм туктату, салым инспекцияләре эшчәнлегенең иминлеген тәэмин итү б-н шөгыльләнә, салым органнарында коррупция б-н көрәш алып бара.

*Е.Б.Долгов.*

**САЛЫНКЫ́ КАНАТЛЫЛА́Р** (Sialis), бөҗәкләр ыругы. Татарстан терр-ясендә бер төре — Sialis lutaria очрый. Гәүдәсе кара төстә, 8–12 *мм* озынлыкта, канатлары коңгырт, ярым үтә күренмәле, җәеме 22–34 *мм*. 2 ел яши, 9 тапкыр кабыгын сала. Тулы әверелешле. Сулыклар янында очрый, начар оча. Күкәйләрен, күч ясап, су һәм яр буе үсемлекләренә яки ташка сала. Чыккан личинкалар суга төшәләр һәм су һәм суда яшәү рәвеше алып баралар. Актив ерткычлар: хирономид, олигохет һ.б.ның личинкалары б-н туеналар. Личинкаларның як-якларында аякларына охшаш трахея саңаклары урнашкан. Артык тирән булмаган, ләмле һәм төбендә үсемлек калдыклары булган агымсыз һәм агымлы сулыкларда яшиләр.

*Әд.:* Жадин В.И., Герд С.В. Реки, озёра, водохранилища СССР, их фауна и флора. М., 1961; Бей-Биенко Г.Я. Общая энтомология. М.,

1966; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977.

*Н.Ш.Әхмәтҗанова.*

**САЛЬВИ́НИЯ** (Salvinia), сальвиниячәләр семьялыгыннан су абагасы ыругы. Якынча 10 төре билгеле, Евразиядә, Төньяк Африкада таралган. Россиядә бер төре — йөзгәләк С. (S. natans) бар, Татарстанда ара-тирә барлык районнарда очрый. Яхшы җылынучы, агымсыз һәм әкрен агымлы сулыкларда үсә. Берьеллык, төрле споралы абага. Тамырчасы горизонталь. Сабагы нәзек, тармаклы, озынлыгы 5–10 *см*. Яфраклары өчәрләп бөҗраккa җыйналган. Ике яфрагы озынча түгәрәк, су өстендә йөзеп йөри, өске ягы ак, аскы ягы коңгырт төкчәләр б-н капланган, өченче яфрагы суга күмелгән, коңгырт төстә, җепсыман сегментларга бүленгән, тамыр рәвешен алган, аның төбендә споралар б-н спорангийлар урнашкан. Бөтен вегетация чоры дәвамында катлама фрагментларыннан бик тиз үрчи. Сентябрь ахыры – октябрьдә үсемлекләр күпләп корый һәм спорангийлары ачыла. Споралар язын тишелеп чыгалар. Тамыр һәм су асты яфраклары маймычларга качу һәм уылдык чәчү урыны булып хезмәт итә. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**СА́ЛЬНИКОВ** Александр Лаврентьевич (11.11.1926, Минзәлә кантоны, хәзер Актаныш р-ны Михайловка пос. — 26.9.1981, шунда ук), колхозчы, Соц. Хезмәт Герое (1966). Хезмәт эшчәнлеген 1942 елда Актаныш р-ның «Чишмә» к-зында башлый, 1945–81 дә бригадир, ферма мөдире. С. җитәкчелегендәге бригада, үсемлекчелек һәм терлекчелектә алдынгы технологияләрне кулланып, а.х. культуралары уңышын күтәрүгә һәм терлекчелек продуктлылыгын 2 тапкыр арттыруга ирешә. Герой исеме бөртекле ашлык җитештерү һәм әзерләүдә ирешелгән уңышлары һәм техникадан нәтиҗәле файдаланганы өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980. Кн. 1; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**СА́ЛЬНИКОВ** Вадим Владимирович (27.10.1956, Приморье краеның Будённовск р-ны Рыбак пос.), биолог, биол. фән. д-ры (2005). Казан ун-тын тәмамлый (1979). РФА КГҮнең Биохимия һәм биофизика ин-тында эшли, микроскопия лаб-ясе мөдире (2008 елда); бер үк вакытта, 1984–99 да, Казан ун-тында. Хезмәтләре үсемлек тукымаларында күзәнәк тышчасының формалашуын өйрәнүгә карый. С. беренче тапкыр озын җитеннең беренчел флоэма сүсләренең морфологиясен тикшерә; сүс җитене сабагында «сыну ноктасын» ача. Иммуноцитохимия алымы ярдәмендә, күзәнәк тышчаларының целлюлоза биосинтезы б-н бәйләп, шикәр синтезы локальләшүен билгели.

Х е з м.: Формирование полисахаридной оболочки у клеток низших и высших растений в схемах. К., 1990; Ультраструктурный анализ лубяных волокон в онтогенезе растений льна // Физиология растений. 1993. Т. 40, № 3 (автордаш); The localisation of sucrose synthase and callose in freeze substitution secondarywall stage cotton fibers // Protoplasma. 2003. № 221 (3–4) (автордаш).

**СА́ЛЬНИКОВ** Юрий Иванович (21.12.1939, Оренбург өлкәсенең Орск ш.), химик, химия фән. д-ры (1987), проф. (1988), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2002). 1962 елда Казан ун-тын тәмамлый, 1963 тән шунда ук эшли, 1987–93 тә нәорганик химия каф. мөдире. Хезмәтләре координацион кушылмалар химиясенә карый. С. сыек фазадагы күп компонентлы катлаулы системада тигезләнешләрне өйрәнү өчен координацион кушылмалар химиясендә төш магнит релаксациясе алымын куллануның теоретик һәм экспериментал нигезләрен; тикшеренүләрнең төрле алымнарында (төш магнит релаксациясе, спектрофотометрия, pH-метрия, потенциометрия, эрүчәнлек алымы, дилатометрия һ.б.) гомуми формаль модельләштерү юлын эшли. Бер яки ике фазалы тигезләнешле сыек фаза системаларында (бериш, төрле лигандлы, күп төшле, гетеротөшле, гетеровалентлы һәм тигезләнешле системаның башка формаларында; электрон күчерүне, ш.у. каты һәм газсыман фазалар хасил булуны исәпкә алып) туры һәм кире мәсьәләләләр чишүнең алгоритмын һәм программасын тәкъдим итә. 3d- һәм 4f-элемент ионнарының кислородлы һәм азотлы лигандлар б-н гомо- һәм гетеротөшле кушылмалар формалаштыру шартларын һәм закончалыкларын билгеләп, координацион кушылмалар химиясендә яңа юнәлеш барлыкка китерә. Уйлап табуга 15 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Магнетохимия и радиоспектроскопия координационных соединений. К., 1989 (автордаш); Полиядерные комплексы в растворах. К., 1989 (автордаш); Кислотно-основные комплексообразующие свойства 2-диалкиламинометилфенолов на примере меди (II) в двухфазной среде тетрахлорметан-вода // Журн. общей химии. 2003. Т. 73, вып. 9 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**СА́ЛЬНИКОВА** Алла Аркадьевна (20.10.1956, Германия Демократик Респ-касы, Плауэн ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1998), проф. (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1979), шунда ук эшли, историография һәм чыганакларны өйрәнү каф. мөдире (2004–15), Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү ин-тының Тарих институты бүлеге мөдире (2013–15). Хезмәтләре илебездә һәм чит илләрдә чыганакларны өйрәнү, Россия тарихын чит илләрдә өйрәнү, тарихи ювенология мәсьәләләренә карый; көндәлек тормыш тарихы мәсьәләләрен, университет мәдәниятe үсешен, гендер тематикасының тарихи аспектларын өйрәнә. «Казан университеты тарихы» («История Казанского университета», 2004) хезмәте авторларының берсе.

Х е з м.: Исторический источник в американской советологии. К., 1997; Российское детство в XX веке: История, теория и практика исследования. К., 2007; Культура повседневности провинциального города: Казань и казанцы в XIX–XX веках. К., 2008 (автордаш); Мультикультурность российского региона как (де) стабилизирующий фактор исторического развития (Среднее Поволжье XIX – начала XXI вв.). К., 2013 (автордаш); Татарская «Алифба»: национальный букварь в мультикультурном пространстве (конец XIX — начало XXI вв.). М., 2014 (автордаш).



А.Л.Сальников.

*Әд.:* Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Биобиблиогр. словарь. К., 1999; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**САМА́Н**, яндырылмаган кирпеч, иң борынгы төзелеш материалларының берсе; башлыча, урмансыз төбәкләрдә тарала. Үзле балчыкка туралган салам яки башка җепселле материаллар (талкыш, кибәк һ.б.) кушып эшләнә. С.ның җылылык үткәрүен киметү һәм суга чыдамлыгын арттыру өчен, 1 $м^3$ балчыкка 15 *кг* чамасы туралган салам (5–10 *см* озынлыкта) кушыла. С. яхшылап шомартыла, тәүлек дәвамында суда җебеми, гадәттә, кысылу ныклыгы 15–25 *кг/см* тәшкил итә; үлчәмнәре (*см*): зурлары — 40×19×13, уртачалары — 36×17×13, ваклары — 33×16×22. 1 $м^3$ С.ның авырлыгы 1400–1600 *кг*. 1950 еллар урталарына кадәр Татарстанда авыл халкының шәхси ярдәмче хуҗалыкларында абзар-куралар, колхоз-совхозларда терлек тораклары С.нан төзелә. Төзелеш материаллары сәнәгате үсү б-н, С. элеккеге әһәмиятен югалта. *Г.Я.Мәүлетова.*

**САМА́РА ГУБЕ́РНАСЫ МӨСЕЛМАННАРЫ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, хәйрия оешмасы. 1907 елның сентябрендә оештырыла. Гамәлгә куючылар: М.Мортазин (рәис), С.Хәлфиев, С.Маннафов, А.Үзбәков, М.Дибердиев, М.Габидуллин, Х.Аптеков, Н.Габидуллов, М.Баишев, З.Шәмсетдинов. Төп максатлары — мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтү, мөселман мәдәнияте, мәгариф оешмаларына булышлык итү. Үз карамагында китапханә тота. Хәйрия эшләрен Самара губернасы күләмендә алып бара. Эшчәнлеге 1913 тә туктала. *Ж.С.Миңнуллин.*

**САМА́РА МӨСЕЛМА́Н ПОЛКЫ́**, 1919 елда Самара интернациональ полкының мөселман батальоны нигезендә оеша. 1918 нең ноябрь–декабрендә Самара шәһәрендә формалаша (декабрь ахырында 1 мең кызылармиячене берләштерә). Мөселман батальоны һәм С.м.п.н оештыручылар — губерна мөселман комис-ты рәисе Г.Г.Садриев һәм Самара интернациональ полкы хәрби комиссары А.А.Хәеров. Полк ирекле рәвештә кушылган, мобилизацияләнгән, башында адмирал А.В.Колчак торган Ак армиядән качкан татарлар хисабына тулыландырыла. Беренче аерым Идел буе татар укчы бригадасы составында сугыш хәрәкәтләрендә катнаша.

*Әд.:* Г и з з а т у л л и н И.Г. Мусульманские военные организации (1917 — 1921 гг.). К., 2002.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**САМА́РА ӨЛКӘСЕ́**, РФ Европа өлешенең көньяк-көнчыгышында, дугасыман борылыш — Самара Дугасы ясалган урында, Идел елгасының урта агымы буенда урнашкан. 1928 елның 14 маенда Урта Идел буе өлкәсе буларак оештырыла, 1929 дан — Урта Идел буе төбәге, 1935 тән — Куйбышев крае, 1936 — 90 нан — Куйбышев өлкәсе. Мәйданы — 53,6 мең *км*². Үзәге — Самара шәһәре. Халкы — 3212676 кеше (1.1.2015). 2010 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 126,1 мең (1959 да — 74,2 мең, 1970 тә — 93,7 мең, 1979 да — 103,6 мең, 1989 да — 115,3 мең, 2002 дә — 127,9 мең) кеше. Татар авылларының күпчелеге өлкәнең төньяк-көнбатышында һәм төньяк-көнчыгышында урнашкан. Татарлар, тупланып, Самара (39409 кеше), Тольятти (28631), Сызрань (8907), Похвистнево (3144), Яңа Куйбышев (2179), Отрадный (1053), Чапаевск (1164), Жигулёвск (1036), Кенәл (1115), Октябрьск (345) шәһәрләрендә һәм ш.у. Камышлы (9160), Похвистнево (6357), Шонталы (3124), Кошки (2258), Чаллыбаш (2097), Идел (2293), Ставрополь (2364), Красный Яр (1620), Елхау (1302), Сызрань (907), Кенәл-Черкас (809), Келәүле (803), Сергиевск (777), Безенчук (617), Нефтегорск (692), Кенәл (690), Зур Черниговка (429), Хворостянка (437), Борское (414), Исаклы (362), Шигоны (331), Приволжье (266), Красноармейское (222), Богатое (237), Зур Глушица (209), Алексеевка (189), Пестравка (125 кеше) р-ннарында яшиләр. Борынгы бабаларыбыз Самара Дугасында Идел буе Болгар дәүләте чорыннан көн күрәләр. Соңрак бу җирләр Алтын Урда составына керә. Хәзерге С.ө.нең төньяк-көнчыгыш өлешендә 16 йөзнең 2 нче яртысында беренче йомышлы татар авыллары — Татар Байтуганы (1553 тә нигез салына), Камышлы (1590) барлыкка килә. Иске Кама аръягы (1652–56) һәм Яңа Кама аръягы (1732–35) чик буе киртәләре төзелә башлау б-н, татарлар Самара Идел аръягының төньяк р-ннарын үзләштерә башлый. Монда хәрби хезмәттәге йомышлы татарлар һәм ш.у. кальга һәм дошманнан саклану корылмаларын төзүдә катнашучы ясаклы татарлар килеп урнаша. 1798 дә Бөгелмә өязендә — 97, Богырысланда 30 татар авылы (Абдулла Заводы, Камышлы, Кармалы-Аделяково, Иске Шалты, Шалты Пүчинкәсе һ.б.) исәпләнә. Бозаулык өязенең көньяк-көнчыгыш өлешендә татарлар Сәет, Медведок, Иске Белогор, Әхмәр, Мөлек, Биккол, Бозаулык Үре авылларына нигез сала. 19 йөз уртасыннан Пенза, Саратов һәм Тамбов губерналарыннан күченгән татарлар Самара Идел аръягының көньяк р-ннарына (Николаевка һәм Яңа Үзән өязләре) урнаша. 1897 елгы халык исәбе буенча, татарлар Самара губернасы халкының 11,2% тан артыгын тәшкил итә. Рев-циягә кадәр барлык татар авылларында (Камышлы, Иске Ярмәк, Мәчәләй, Яңа Мансурда — 4әр) мәчет эшли. Самарада беренче мәчет 1856 да ачыла (1890 га кадәр эшли), 1892 дә эшмәкәр Т.К.Акчурин (к. *Акчуриннар*) икенче мәчетне төзетә, 1912 дә өченче мәчет ачыла (мәчетләр каршында мәктәп һәм мәдрәсәләр эшли). Иске Ярмәк авылында 2 мәдрәсә була, 1903 тә кыз балалар өчен мәктәп ачыла. Бөгелмә өязенең Бәйрәкә авылындагы «*Гобәйдия*» мәдрәсәсе иң атаклы мөселман уку йортларының берсе була. 1907–13 елларда *Самара губернасы мөселманнары җәмгыяте* эшли, 1908–13 тә татар телендә «*Икътисад*» ж-лы нәшер ителә. 1917 дән соң милли-мәдәни тормышта җанлану күзәтелә. 1918 нең ноябреннән Самарада Мөселман коммунистлар ком-ты (к. *Мөселман коммунистлар комитетлары*) эшли, 1920 дә халык мәгарифенең губерналар бүлеге каршында Милли азчылык советы оештырыла. 1919 да — *Самара мөселман полкы*, Аерым татар кавалерия дивизионы, 1920 дә Богырыслан шәһәрендә Хәлиткеч һөҗүм ясый торган ирекле аерым татар батальоны төзелә. Татар телендә «*Безнең фикер*» (1918), «*Киңәш*» (1918), «*Кызыл дөнья*» (1918–20), «*Урак-Чүкеч*» (1919), «*Яңа көч*», «*Идел арты хәрби-сәяси идарәсе хәбәрләре*» (1920), «*Эшче*» (1921–22), «*Авыл*» (1922–24), «*Кызыл Армеец*» (1924), «*Яңа дөнья*» (1924–25) г-талары, «*Урта Идел*» (1928–29), «Комбайн» (1932–33), *Методик җыентык* (1931–33) ж-ллары нәшер ителә.




«Самар татарлары» («Самарские татары») журналы. 2014.

1929 да Самарада СССР Халыклары үзәк нәшриятының Урта Идел буе бүлекчәсе ачыла, һәм ул 1931 гә кадәр төрле тематикадагы 119 татар китабы чыгара. 1920 дә *Самара татар драма һәм музыка студиясе* һәм Камышлы авылында һәвәскәр театрга (1972 дән — халык театры) нигез салган драма түгәрәге оештырыла. 1920 еллар ахырында милли азчылыкның Самара клубы каршында татар бүлеге эшли, спектакльләр куела, татар язучылары һәм шагыйрьләре б-н очрашулар үткәрелә. 1930 еллар башында хәзерге С.ө. терр-ясендә 435 татар мәктәбе (1157 укытучы 46600 балага белем бирә) эшли. Татар яшьләре пед. һәм а.х. техникумнарында, совет партия һәм мед. хезмәткәрләре мәктәпләрендә һ.б.ш. уку йортларында белемне үз туган телендә ала. 1929 да татарлар күпләп яшәгән Сок елгасының югары агымы буенда Байтуган (1937 дән — Камышлы) татар р-ны оештырыла (1960 еллар башында Похвистнево р-нына кушыла). 1930 елларда татар милли-мәдәни тормышы торгынлык чоры кичерә. Мәчетләрнең күбесе ябыла, руханилар репрессияләнә. Сабан туен бәйрәм итү Камышлы һәм Иске Ярмәк авылларында гына сакланып кала, Татар мәктәпләренең саны кискен кими. 1980 еллар ахырында С.ө. татарларының иҗтимагый-мәдәни тормышы җанланып китә. 1989 дан «Туган тел» татар өлкә мәдәни үзәге (Похвистнево, Сызрань, Тольятти шәһәрләрендә бүлекчәләре бар), аның каршында «Яшь зыялы» татар яшьләре клубы эшли. 1992 дә Самарада «Азатлык» Татар-башкорт яшьләр берлеге, 1997 дә Шонталы р-нында «Нур» татар җәмгыяте, 2001 дә Самара һәм Тольяттида татарларның милли-мәдәни автономиясе оештырыла. 2011 дә Самара өлкәсенең татар эшмәкәрләренә ярдәм ассоциациясе барлыкка килә. «Туган тел» җәмгыяте башлангычы һәм ассоциациянең матди булышлыгы б-н 2012 дән татар һәм рус телләрендә «Самар татарлары» («Самарские татары») ж-лы чыгарыла. 1990 нан Самарада атнага 1 тапкыр татар телендә «Бердәмлек» иҗтимагый-сәяси г-тасы (баш мөхәррире — Р.Н.Әһлиуллин), 1996 дан рус телендә айга 2 тапкыр «Азан» г-тасы нәшер ителә. 1992–2002 дә «Радио-7 из Самары» радиостанциясендә «Ак бәхет» татар редакциясе эшли. Хәзерге вакытта татар тапшырулары «21 век — Самара» радиостанциясе дулкынында трансляцияләнә. 1989 дан «Самара» Дәүләт телерадиотапшырулар компаниясе радиодулкынында «Иделкәем — илкәем» тапшыруы чыга. 2004 тә «АвтоВАЗ» АҖ телевидениесендә атнага 1 тапкыр Тольятти татарлары тормышына багышланган тапшыру күрсәтелә. С.ө.ндә башлангыч һәм урта 19 татар мәктәбе исәпләнә, 1989 дан Самарада татар телен һәм мәдәниятен тирәнтен өйрәнүче «Яктылык» милли мәктәбе һәм аның каршында якшәмбе мәктәбе эшли. 2002 дән Тольяттиның 3 гомуми белем бирү мәктәбендә татар тарихы һәм мәдәнияте укытыла, татар халкының шөгылен һәм милли киемнәрен өйрәнүче түгәрәкләр оештырыла; 2005 тән 81 нче мәктәп җирлегендә якшәмбе гуманитар татар мәктәбе эшли. Ел саен татар теленнән олимпиадалар үткәрелә. С.ө.ндә 30 лап татар үзешчән коллективы, ш.и. Самарада «Дуслык» татар яшьләре ансамбле (1965 тән), «Ялкынлы яшьлек» (1970 тән; 1977 дән — халык ансамбле), «Идел» эстрада ансамбле (1996 дан; 2000 нән — халык), «Таң йолдызлары» балалар ансамбле (1994 тән), «Ләйсән» бию-хореография ансамбле һәм «Яктылык» мәктәбе каршында «Җидегән чишмә» эстрада-вокаль ансамбле; Тольяттида татар милли хоры, вокаль һәм хореография төркемнәре; Сызраньда «Шатлык» ансамбле; Иске Ярмәк авылында «Ак каен» фольклор ансамбле (1970 тән; 1989 дан — халык ансамбле); Камышлы р-нында «Заман» ансамбле, Камышлы авылында «Корнай» эстрада төркеме (1990 нан; 1993 тән — халык), Шонталы р-ның Денис авылы Мәдәният сарае каршында «Чулпан» фольклор ансамбле эшли.

С.ө.ндә *Сабан туе, Нәүрүз,* «Сөмбелә», «Уйнагыз, гармуннар» бәйрәмнәре, *көрәш* турнирлары, татар поэзиясе көннәре, балалар өчен бәйрәмнәр, дискотекалар уздырыла. 2002 дә Тольятти шәһәрендә федераль Сабан туе, 2010 да Похвистнево р-нының Гали авылында I Бөтенроссия авыл Сабан туе була. 1994 тә «Театр язы» өлкә фестивале үткәрелә, 1999 да Идел буе Болгар дәүләтендә ислам кабул итүгә багышланган Татар мәдәнияте көннәре үткәрелә. 1994 тән С.ө.ндә Мөселман диния нәзарәте эшли. 78 мәчет һәм 4 мәдрәсә (Гали, Денис, Камышлы, Кенәл-Черкас авылларында), «Минниса» мөселман хатын-кызлар оешмасы, Ислам иҗтимагый-сәяси үзәге (Тольятти) эшли. Актёрлар З.Г.*Солтанов*, Р.М.*Шамкаев*, балет артисты Н.М.Гыймадиев, ТРның халык артисты Р.Ш.*Вәлиев*, генерал-лейтенант Ә.Н.*Рамазанов*, Сов. Союзы Геройлары Ф.Ә.*Сабиров*, О.А.*Санфирова*, Соц. Хезмәт Герое Г.С.*Сабирҗанов*, нәкышьче Н.З.*Бикколов*, журналист Ф.Ш.Мортазин, тарихчылар Җ.И.*Гыйльманов*, Г.С.*Сабирҗанов*, тел белгече Л.Җ.*Җәләй*, әдәбият галиме И.З.*Нуруллин*, педагоглар С.Г.*Вагыйзов*, М.*Абдрахманов*, язучылар Г.*Кутуй*, Х.Г.*Садри*, М.Чулпаный, сәяси эшлеклеләр Г.Б.*Ашмасов*, Ш.С.*Измайлов*, шагыйрьләр Ә.М.*Давыдов*, Г.Ш.*Сәгыйров*, Д.*Фәтхи*, Дан орденының тулы кавалеры Х.М.*Миңнекәев*, дин эшлеклесе З.*Шаһгәрәев*, спортчылар Р.М.Галәлетдинов, Һ.Х.*Бикташев*, физиолог Р.Ш.*Габдрахмановның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге С.ө. б-н бәйле.

*Әд.:* Ведерникова Т.И. Расселение татар в Степном Заволжье (Самарской губернии) в XVIII–XIX вв. // Проблемы истории СССР: Сб. статей. М., 1981. Вып. 12; Уразманова Р.К. Годовой цикл традиционных обрядов и праздников татар в деревнях Старое Ермаково, Старая Балыкла, Татарский Байтуган, Новое Усманово и селе Камышла Камышлинского района Самарской области // Самарская область. Этнос и культура. Самара. 1997.

**САМА́РА ТАТА́Р ДРА́МА ҺӘМ МУ́ЗЫКА СТУ́ДИЯСЕ**, уку йорты. 1920 елда Идел аръягы хәрби округы сәяси бүлегенең мөселман секциясе каршында оеша. Оештыручылары һәм җитәкчеләре — З.Солтанов, И.Рәмиев, укытучылары һәм режиссёрлары — К.Тинчурин, П.Толбузин. Укучылары арасында М.Әбсәләмов, Х.Уразиков, Ә.Мәҗитов, Т.Гыйззәт була. Дәресләр З.Солтанов эшләгән программа буенча уздырыла, ш.у. тиз оештырылучан сәхнә күренешләре, этюдлар, татар драматурглары пьесаларыннан өзекләр әзерләү дә кертелә. Дәресләр барышында әзерләнгән диплом спектакльләре: «Беренче адым» (Ш.Усманов), «Беренче чәчәкләр», «Соңгы сәлам» (К.Тинчурин). Студияне тәмамлаучылар 1920–21 дә Оренбург шәһәрендә эшләп килүче «Г.Кариев исем. беренче пролетком труппасы»на (башка исеме — «Г.Кариев хатирәсе труппасы») берләшә.

**САМАРСА́У** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Имәнле елгасы буенда. 2010 елда 1 кеше яши. 19 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Степановка исеме б-н дә билгеле. Крәстияннәр башта крепостной булалар, соңрак алпавыт аларны ирекле игенчеләр итеп күчерә; игенчелек, терлекчелек, вак һөнәрчелек, олаучылык б-н шөгыльләнәләр. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, монда су тегермәне була. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 370 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Тәкмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1895 тә — 77, 1913 тә — 273, 1920 дә — 269, 1926 да — 119, 1938 дә — 141, 1949 да — 159, 1958 дә — 112, 1970 тә — 49, 1979 да — 19, 1989 да — 6, 2002 дә — 3 кеше (руслар).

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.



Ю.И.Самарский.

**САМА́РСКИЙ** Юрий Иванович (4.4.1948, Рязань өлкәсенең Рязань р-ны Солотча пос. — 18.4.2008, Казан), валторначы, педагог, ТАССРның халык артисты (1987), проф. (2004). 1968 елда — Рязань музыка уч-щесен, 1973 тә Казан консерваториясен (Е.И.*Картухин* классы) тәмамлый. 1969–94 тә ТРның Дәүләт симф. оркестрында музыкант (1972 дән концертмейстер), бер үк вакытта, 1972–2004 тә, Татар опера һәм балет театры оркестрында музыкант. 1992 дән Казан консерваториясендә укыта, 1997–2008 дә тынлы һәм бәрмә музыка уен кораллары каф. мөдире. 2001 дән Казан консерваториясенең тынлы музыка уен кораллары оркестрын җитәкли, аның җитәкчелегендә 20 дән артык программа башкарыла. С.ның иҗат манерасы индивидуальлеге, саф интонациясе, валторнаның тәэсирле яңгырашы б-н аерылып тора. Аның катнашында классик һәм хәзерге заман музыкасы, ТР композиторларының беренче тапкыр башкарылган әсәрләре яздырыла. С. классын тәмамлаучылар — 20 дән артык халыкара һәм бөтенроссия фестивальләре лауреатлары. Казанда 1 нче һәм 2 нче бөтенроссия тынлы музыка уен кораллары ансамбльләре конкурсларын (2004, 2007) уздыруны башлап йөрүче.

Хезм.: Шесть романсов татарских композиторов (переложения для валторны и фортепиано). К., 1998.

**САМА́РЦЕВ** Виталий Владимирович (29.10.1939, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1981), проф. (1990), ТРның, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1995, 2001). 1966 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1969 дан РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли, баш фәнни хезмәткәр (1986–89, 1993–97), нәсызыкча оптика лаб-ясе мөдире (1989–93, 1997 дән), бер үк вакытта Казан химия-технол. ин-ты (1986–90) һәм Казан ун-ты (1990 нан) профессоры. Хезмәтләре нәсызыкча һәм когерент оптикага карый. С. экситон кайтаваз, экситон үзиндуцияле үтә күренмәлелек һәм экситон үтә нурланыш (1971), сызыкча оптик кайтаваз-спектроскопия (1978) күренешләрен алдан әйтә. Фотон кайтавазы сигналлары формасының ярсыткыч лазер импульслары формасы б-н корреляциясе күренешен ачыклый һәм аңлата. Беренчеләрдән булып, каты җисемдә оптик үтә нурланыш һәм озак дәвам итүчән фотон кайтавазы сигналлары буенча тәҗрибәләр үткәрә, шуның нигезендә оператив истә калдыру җайланмасы төзи. Озак дәвам итүчән фотон кайтавазы сигналының күп тапкырлар укылу эффектын, триггерлы оптик үтә нурланыш күренешен ача. Нәсызыкча һәм квант оптикасында когерент һәм күмәк күренешләргә караган хезмәтләр циклы өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2009). Татар энциклопедиясенең «Физика» бүлеге буенча гыйльми мөхәрририяте әгъзасы (1992 дән). Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Оптическая эхо-спектроскопия. М., 1984 (автордаш); Фотонное эхо и его применение. К., 1988 (автордаш); Лазерное охлаждение твёрдых тел. М., 2005 (автордаш); Оптика фемтосекундных лазеров. СПб., 2007 (автордаш).

**САМА́РЦЕВО**, к. *Самарсау*, Зәй р-ны.

**«САМА́Т»**, опера, композитор Х.В.Вәлиуллинның кереш бүлек б-н 4 күренештәге әсәре. Х.Вахит либреттосы. Премьерасы 1957 елның 9 мартында Татар опера һәм балет театрында була, май аенда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында күрсәтелә. Дирижёры Х.В.Фазлуллин, режиссёры Н.К.Даутов, рәссамы Ә.Х.Нагаев, Самат ро-





Х.В.Вәлиуллинның М.Җәлил исем. Татар опера һәм балет театрында куелган «Самат» операсыннан күренешләр: 1. Үзәктә — Самат ролендә А.З.Аббасов. 1957; 2. Сулдан уңга — Әлфия ролендә Р.Х.Мифтахова, Разия ролендә Х.Г.Гыйниятова. 1977.

лендә — А.З.Аббасов, У.Г.Әлмиев, Н.К.Даутов, Әлфия ролендә — Ф.Т.Тимерова, З.Г.Хисмәтуллина. 1977 дә операның драматургик конфликты ачыграк сурәтләнгән икенче редакциясе куела. Дирижёры И.А.Лапиньш, режиссёры Н.К.Даутов, рәссамы Э.Х.Нагаев. Рольләрдә: Самат — Х.А.Бигичев, Әлфия — Р.Х.Мифтахова, З.Д.Сөнгатуллина, Разия — Х.Г.Гыйниятова. Вакыйга татар авылында Бөек Ватан сугышына кадәрге һәм сугыштан соңгы чорда бара. Фольклор үрнәкләре файдаланылган лирик музыка төзеклеге, баш геройларның тирән һәм катлаулы кичерешләре, куелышның матурлыгы заманча лирик-психол. спектакль тудыру мөмкинлеге бирә. 1989 да Х.В.Вәлиуллин ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә лаек була.

*Р.И.Такташ.*

**САМА́ТОВ** Габделхак Гата улы (12.10.1930, Аксубай р-ны Иске Ибрай а. — 6.3.2009, Казан), дин эшлеклесе. 1954 елдан Казан пр-тиеләренең берсендә шофёр булып эшли. «Мир-Араб» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң (Бохара ш., 1968), респ-каның мөселман җәмгыяте тормышында актив катнаша. 1978–81 дә Мәрҗани мәчетендә эшли. Әлмәт (1981 дән), Оренбург (1986 дан), Чистай (1988 дән), Казандагы Мәрҗани мәчетендә (1991 дән) имам-хатиб. 1992–98 дә ТР Мөселманнары Диния нәзарәтендә баш имам-мөхтәсиб, 1998–2006 да баш казый, 2006 дан мактаулы казый. Казандагы Ислам кабул итүнең 1000 еллыгы исем. мәчеткә нигез салучыларның берсе (1990). Баку (Әзәрбайҗан, 1986), Җиддә (Согуд Гарәбстаны, 1990) шәһәрләрендә узган ислам конференцияләрендә катнаша. Хезмәтләре шәригать гыйлеменә карый. Халыклар дуслыгы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Шәригать: Вәгазь, хөкем, фәтва, җавап-савап, киңәшләр: 3 китапта. К., 2005–06.

**СА́МБО** (үз-үзеңне коралсыз саклау), спорт көрәше төре, нигезендә төрле милли көрәш төрләрендә кулланыла торган иң нәтиҗәле алымнар ята. Спорт төре буларак СССРда 1938 елда барлыкка килә. Татарстанда 1950 елларның 2 нче яртысыннан үсеш ала (башлап җибәрүчеләре — «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте вәкилләре С.К.Камалов, В.М.Сергеев). С. 1957 дән профсоюзларның «Труд», «Трудовые резервы», «Буревестник», «Зенит», «Урожай» (1987 гә кадәр) респ-ка ирекле спорт җәмгыятьләрендә, «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә, мәгариф, физик культура һәм спорт дәүләт органнары идарәләре каршындагы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләре бүлекләрендә җәелдерелә. 2010 да Татарстанда Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләре каршында (шуларның 2 се олимпия резервындагы), спорт комплексларында, Казан, Чаллы, Түбән Кама, Яшел Үзән, Чистай, Алабуга, Азнакай, Менделеев, ш.у. Спас (Болгар ш.), Ютазы (Урыссу штп), Апас (Апас а.), Аксубай (Аксубай штп), Кукмара (Кукмара штп) р-ннарындагы «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятьләрендә якынча 20 бүлек һәм секция эшли. Татарстанның С. буенча җыелма командасы — РСФСР халыклары спартакиадасында көмеш медаль (1972) ала. 1978 дән Татарстан спортчылары (1994 тән хатын-кызлар) СССР, Россия, Европа, дөнья беренчелекләрендә катнаша. 1990 нан Казанда ел саен С. буенча Нәкыйп Мадьяров истәлегенә Бөтенроссия турниры, 1994 тән Ә.Г.Шәрәфетдинов истәлегенә Респ-ка турниры, 2001–02 дә «Витязь» призына яшүсмерләр арасында турнир уздырыла. 2016 да ТРда С. б-н 3 меңнән артык кеше шөгыльләнә (шуларның 600 е хатын-кызлар), ш.и. балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләрендә 1 меңнән артык. 1994–98 дә ТР С. федерациясе Халыкара самбо федерациясенә, 1998 дән Бөтенроссия самбо федерациясенә керә. ТРның иң яхшы спортчылары — СССР, РСФСР, Россия, Европа, дөнья (ш.и. яшьләр, полиция хезмәткәрләре арасында) беренчелекләре, чемпионатлары һәм Кубокларында медаль алучылар һәм җиңүчеләр: С.Н.Алеханов, Н.Ю.Ашеулова, А.Н.Вәлиев, Э.А.Водящев, В.А.*Волков*, З.Р.*Гарипова*, А.Ф.Зәйнетдинов, А.Р.Карасёв, А.Ковязина, А.В.Кухаренко, Мадьяровлар: Рәфыйк Ә., Нәкыйп Ә., Нәфыйк Ә. һәм Фәрит Ә., В.Н.Рябов, И.Р.Сәләхов, И.А.Чичканов. ТРның иң яхшы тренерлары — Р.С.Әхмәтгәрәев, В.И.Вандышев, Р.Ю.Галимҗанов, М.Г.Галимуллин, А.Г.Заһретдинов, Р.Х.Касыймов, Ф.Ә.Мадьяров, Р.Т.Сабиров, З.В.Сәгъдиев, В.М.Сергеев, Р.Г.Сөнгатуллин, И.А.Чичканов, А.Шабуров. Татарстанда самбо федерациясе җитәкчеләре — Ф.Ә.Мадьяров (1976–93), И.Г.Галимов (1993–98), С.А.Когогин (1998–2004); 2004 тән — И.М.Егоров. Казанда С. буенча ярышлар уздыру өчен халыкара таләпләргә туры килүче спорт корылмалары — «Татнефть Арена» спорт сарае, «Ак Барс» көрәш сарае, «Олимпиец» спорт комплексы, «Олимп» спорт залы.

**САМИ́НОВКА** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 17 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 84 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көненнән — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1949 да — 199, 1958 дә — 138, 1970 тә — 143, 1979 да — 132, 1989 да — 87, 2002 дә — 88 кеше.

**СА́ММЕР** Иван Адамович (3.9.1870, Киев губ. Очеретная а. — 25.6.1921, Харьков ш.), революцион хәрәкәт эшлеклесе. 1891–95 елларда Киев ун-тында укый, аннан соң Полтава земство идарәсендә эшли. Революцион хәрәкәттә катнаша. 1897 дә С.-Петербургка күченеп китә, «Эшчеләр сыйныфы азатлыгы өчен көрәш союзы» («Союз борьбы за освобождение рабочего класса») әгъзасы. 1898 дә кулга алына, 1899 да Самарага җибәрелә, 1900 дә 3 елга хөкем ителеп, Великий Устюг, Вологда шәһәрләрендә (Вологда губ.) сөргендә була. 1904–05 тә РСДРПның Казан ком-ты әгъзасы, РСДРПның 3 нче съезды делегаты (Лондон, 1905). РСДРП ҮКның Рус бюросы секретаре (1905 тән). 1905 нең октябрендә Казанда кораллы күтәрелеш җитәкчеләренең берсе, *Казан шәһәр коммунасы* (19–21 октябрьдә Казанда революцион үзидарә органы) әгъзасы. 1905 нең декабрендә Мәскәүдә кораллы күтәрелеш җитәкчеләренең берсе. 1906 да РСДРПның Таммерфорс шәһәрендә (Финляндия) узган Бөтенроссия хәрби һәм сугышчан оешмалар конференциясендә РСДРП ҮК вәкиле. 1907 дә кулга алына, 1909 да Вологда губернасына җибәрелә. 1909 дан Вологда шәһәрендә, 1917–19 да Вологда эшче һәм солдат депутатларының Вологда советы Президиумы әгъзасы, губерна башкарма ком-ты рәисе урынбасары, Вологда ХХС рәисе. 1919–21 дә Центросоюз идарәсе (Мәскәү) әгъзасы, Украина кулланучылар җәмгыятьләре берлеге рәисе, РСФСР Тышкы сәүдә халык комис-тының Украинадагы вәкиле, Украина ХКС һәм ҮБК әгъзасы.

*Әд.:* Э л е р т А.А. Саммер Иван Адамович // Борцы за счастье народное. К., 1967; ш у л у к. «Усиленно Вам его рекомендуем...»: Жизнь, революционная и государственная деятельность И.А.Саммера. К., 1982.

**«САМОДЕ́ЯТЕЛЬНОСТЬ»** («Үзешчәнлек»), айлык кооператив журнал. Казанның «Хезмәт берлеге» кулланучылар җәмгыяте органы. 1909 елның декабреннән 1910 ның мартына кадәр рус телендә нәшер ителә, барысы 3 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — Д.С.Уханов. «Иҗтимагый-мәдәни тормыш мәсьәләләренә багышланган журнал» дигән өстәмә башы була. Мәкаләләрдә Россиядә, аеруча халыкның төрле формадагы үзара ярдәм җәмгыятьләре оештыруда катнашкан түбән катлавы арасында иҗтимагый үзешчәнлекнең сизелерлек үсеше билгеләп үтелә. Редакция Казан һәм губерна, кооператив һәм профсоюз оешмалары тормышын һәрьяклап яктыртырга, эшчәнлекләренең теоретик һәм практик мәсьәләләрен хәл итәргә омтыла. Материалларның күп өлеше «Хезмәт берлеге» һәм аның каршында оешкан Ссуда-саклык ширкәте эшенә, приказчикларның ярдәмче җәмгыяте, коммерция хезмәткәрләре һәм хисапчылары оешмалары, Рус җир бүлеп бирүчеләр оешмасының Казан бүлеге, Алафузов кулланучылар оешмасы һ.б. эшчәнлеген анализлауга багышлана. Казан торак төзелеше кооперативлары оештыру проблемаларын күтәрә. Оешмаларның хисап документлары формасы һәм эчтәлеге, җыелыш һәм съездлар уздыру даимилеге («Хезмәт берлеге»нең Ссуда-саклык ширкәтенең 1909 ел хисаплары басыла) турындагы мәсьәләне куя. Россиядә кооператив хәрәкәте үсеше хроникасы басыла.

*Р.А.Айнетдинов.*

**САМО́ЙЛОВ** Александр Николаевич (23.1.1964, Казан), педиатр, офтальмолог, мед. фән. д-ры (2007), проф. (2013), ТРның атказ. табибе (2008). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1987), Респ-ка күз авырулары хастаханәсендә эшли. 2007 елдан Казан мед. ун-тының күз авырулары кафедрасында. Хезмәтләре күз авыруларын дәвалауга, вертеброневрологиягә карый. С. тарафыннан күрү әгъзаларының муен остеохондрозы б-н бәйле тайпылышлары һәм авыруны кисәтү, күзнең мөгез катлавын дәвалау (ш.и. йомшак линзалар кулланып) мәсьәләләре өйрә-

нелә; 4 монография авторы. Уйлап табуга 2 патенты бар. ТР Офтальмологлар җәмгыяте рәисе (2010 нан).

Х е з м.: Этапы становления и развития педагогического процесса на кафедре офтальмологии Казанского медицинского университета // Казан. мед. журн. 2012. Т. 93. № 6; Саркоидоз глаз в мировой практике, история изучения // Казан. мед. журн. 2012. Т. 93. № 6.

**САМО́ЙЛОВ** Александр Филиппович (26.3.1867, Одесса ш. — 22.7.1930, Казан; Мәскәүдә җирләнә), физиолог, медицина д-ры (1891), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1930). Медиаторлар турындагы тәгълиматка һәм Россия электрофизиол. мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Дерпт (хәзер Тарту) ун-тын тәмамлый (1891). Эксперименталь мед. ин-тында И.П.Павлов (С.-Петербург, 1892 елдан) һәм Мәскәү ун-тында И.М.Сеченов (1894 тән) физиол. лаб-яләрендә эшли. 1903 елдан Казан ун-тында: проф., физика-матем. (1924–30) һәм мед. (1929 дан) ф-тларында физиол. кафедралары мөдире. Бер үк вакытта Мәскәү вет. ин-тының физиол. каф. профессоры (1921 дән) һәм Мәскәү ун-тының физика-матем. ф-тының хайваннар физиологиясе каф. мөдире (1924 тән). Хезмәтләре физиологиягә карый. С. — йөрәк физиологиясен тикшерүнең оригиналь алымнары авторы. Россия электрокардиография фәнен теоретик нигезли. 1906 да, Россиядә беренче булып, кешенең электрокардиограммасын яздыра һәм электрокардиографик тикшерү алымын клиникаларда гамәлгә кертә. Нервтан мускулларга, нейроннан башка нейронга ярсыну күчешенең химик халәте турындагы фаразны нигезли. Музыка теориясе өлкәсендә тикшеренүләр үткәрә, бу исә аны музыка ладларын өйрәнүче зур белгечләр б-н бер рәткә куя. В.И.Ленин исем. бүләк лауреаты (1930). Казан ун-тының төп бинасына һәм Казанда ул яшәгән йортка (Мөштәри ур.) мемориаль такта куелган.

Х е з м.: Электрокардиограммы // Рус. врач. 1908. № 33; О переходе возбуждения с двигательного нерва на мышцу // Сборник, посвящённый 75-летию И.П.Павлова. Л., 1924; Кольцевой ритм возбуждения // Науч. слово. 1930. № 2; Избранные статьи и речи. М.–Л., 1946.

*Әд.:* Г р и г о р я н Н.А. Александр Филиппович Самойлов. М., 1963.

*Н.В.Звёздочкина, А.Л.Зефиров.*

**САМО́ЙЛОВ** Владимир Васильевич (8.9.1962, Лениногорск ш.), инженер-электрик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007). Лениногорск нефть техникумын (1982), Ульянов политехник ин-тын (1992) тәмамлый. 1982 елда «Татнефть» АҖдә эшли: контроль-үлчәү приборлары һәм цех автоматикасы буенча слесарь, инженер-программист, әйдәп баручы инженер (1993 тән), «Иркеннефть» НГДУында баш инженер урынбасары (1998 дә), хисаплау техникасын автоматлаштыру һәм контроль-үлчәү приборлары бүлеге башлыгы урынбасары (1998 дән), «ТатАСУнефть» идарәсе башлыгы (2002 дән). Дәүләт бүләге автоматлаштырылган проектлау технологияләре нигезендә нефть чыганакларын эшкәртү б-н идарә итү алымнары булдыруда һәм сәнәгатьтә кулланылышка кертүдә катнашуы өчен бирелә.

Х е з м.: Построение интегрированной телемеханической системы НГДУ «Иркеннефть» // Геология, разработка и эксплуатация Абдрахмановской площади: Сб. науч. трудов. Уфа, 1997. Вып. 1 (автордаш); Проект внедрения многоуровневой АСУТП ДИСК-110 и ПроТок АО «ТАТНЕФТЬ» // Нефтегаз. 2000. № 4 (автордаш); Имитационное исследование системы сервисного обслуживания средств вычислительной техники и программного обеспечения АО «Татнефть» // Автоматизация в промышленности. 2007. № 3 (автордаш).

**САМО́ЙЛОВ** Григорий Самуилович (6.11.1909, Казан — 6.1.1975, шунда ук), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1969). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1931), Чистай шәһәрендә, үзәк район хастаханәсендә эшли. 1935–41, 1946–1975 елларда Казан ГИДУВының ортопедия һәм травматология кафедрасында; бер үк вакытта Травматология һәм ортопедия фәнни-тикшерү ин-тында. 1941–45 тә Бөек Ватан сугышы фронтларында (фронт госпитальләренең әйдәп баручы хирургы). Хезмәтләре травматология мәсьәләләренә, аяк сыну очракларында компрессион фиксация алымын куллануга, терәк-хәрәкәтләнү аппараты травмаларын кисәтүгә карый. Тез капкачын пластмасса протез б-н алыштыру ысулын уйлап табуга патенты бар. 1 нче, 2 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы орденнары, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К вопросу об иннервации костей голени // Архив анатомии, гистологии и эмбриологии. 1956. № 1; О лечении переломов надколенника // Ортопедия и травматология. 1956. № 6; Лечение переломов костей нижних конечностей. К., 1961; Дольчатый надколенник // Казан. мед. журн. 1965. № 5.

*Әд.:* Доцент Григорий Самуилович Самойлов // Казан. мед. журн. 1975. № 4.

**САМО́ЙЛОВ** Григорий Фадеевич (2.2.1935, Казан — 6.7.1989, шунда ук), төзүче-инженер. Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлаганнан соң (1958), «Казаньхимстрой» трестының 3 нче төзү-монтаж идарәсендә прораб, өлкән прораб булып эшли. 1961–65 елларда ВЛКСМның Казан шәһәр ком-ты секретаре, КПССның Казан шәһәр ком-тында бүлек мөдире. 1965–87 дә (бүленеп) «Главтатстрой» идарәсендә: баш инженер, 5 нче төзелеш тресты управляющие, идарә башлыгы урынбасары. 1967–73 тә Татарстан «Татсельстрой» җитештерү идарәсе башлыгы. 1987–89 да КПССның Татарстан өлкә ком-ты секретаре. С. җитәкчелегендә Татар акад. театры, Көнкүреш һәм модельле аяк киемнәре йорты, Казан төзүче инженерлар, Казан авиация ин-тлары уку корпуслары һ.б. төзелә. Авыл җирләрендә күчмә механикалаштырылган колонналар оештыручы. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**САМО́ЙЛОВ** Дмитрий Николаевич (24.7.1967, Казан), а.х.н механикалаштыру өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2007). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1992), Казанның коммерция оешмаларында эшли. 2003 елдан Казан техник ун-тының двигательләр һәм сервис кафедрасында. Хезмәтләре двигательләрнең җылылык-физика процессларына һәм җылылык-энергетика ресурсларын өйрәнү өлкәсенә карый. С. ЗМЗ-4021.10 бензин двигательләренең эшен катламлы заряд кулланып тикшерә һәм аның егәрлекне арттыруын, ягулык чыгымын һәм янган газларда агулы кушылмалар күләмен киметүен күрсәтә. Автомобиль һәм тракторларга өстәмә бөтерелмәле двигательләр урнаштырганда мөмкин саналган агулылык нормаларының тотрыклы кимүен билгели. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар.




А.Ф. Самойлов.

Х е з м.: Автомобильный транспорт — основной источник загрязнения окружающей среды и способы его уменьшения. К., 2000 (автордаш); Теплофизические процессы и характеристики бензиновых и дизельных двигателей с дополнительным завихрением и расслоением заряда. К., 2004; Топлива, смазочные материалы, технические жидкости. К., 2007 (автордаш).

**САМО́ЙЛОВ** Николай Павлович (18.12.1926, Арча кантоны Семиозёрка а.), а.х.н механикалаштыру өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1994), проф.(1996), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). 1962 елда Мәскәү машиналар төзү ин-тын тәмамлый. 1950–65 тә Казан пр-тиеләрендә эшли. 1965 тән Казан аграр ун-тында: укыту үзәге башлыгы (1965–67), проректор (1967–80), хезмәтне саклау һәм производствога өйрәтү каф. мөдире (1980–85), тракторлар һәм автомобильләр каф. профессоры (1985 тән). Хезмәтләре ягулык-энергетика ресурсларына һәм автомобиль, тимер юл, елга транспорты эше б-н бәйле экология мәсьәләләренә карый. С. двигательләрнең агулы зыянын киметү максатында бензин двигательләрендә янучан катнашма ясалу системаларын, сыек һәм ялкынлы нейтральләштергечләр эшли; катнашма янганда ялкын таралу тизлеген билгеләүнең матем. моделен тәкъдим итә. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре.

Х е з м.: Автомобиль повышенной проходимости ВАЗ-2121 «Нива». К., 1995; Бензиновые двигатели с подачей в цилиндры дополнительного воздуха. К., 1995 (автордаш); Токсичность автотракторных двигателей и способы её снижения. К., 1997 (автордаш).

**САМОЙЛО́ВИЧ** Александр Николаевич (17.12.1880, Түбән Новгород ш. — 13.2.1938, Мәскәү өлкәсенең Ленин р-ны Коммунарка пос.), шәркыятьче галим, тюрколог, төрек-татар теле һәм әдәбияты магистры (1915), СССР ФА академигы (1929; 1924 елдан мөх-



Р.С.Саморуков.

бир әгъза). Дворяннар нәселеннән. 1903 тә Петербург ун-тын (1914 тән Петроград, 1924 тән Ленинград ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: приват-доцент (1906–17), экстраординар проф. (1917–18), проф. (1918–30). Бер үк вакытта, 1920–37 дә, Ленинград шәрекъ ин-ты проф. (1922–25 тә ректоры). 1929–33 тә СССР ФАнең гуманитар фәннәр бүлеге акад. секретаре. 1934–37 дә СССР ФАнең Шәрекъне өйрәнү ин-ты директоры. Кырым, Идел буе, Төньяк Кавказ, Кавказ арты, Урта Азия, Казакъстан, Алтай төрки телле халыкларының телен, фольклорын, көнкүреш тормышын өйрәнә. СССРның кайбер халыклары язуын булдыруда катнаша. Беренче Бөтенсоюз тюркология съездын оештыручыларның берсе (Баку, 1926). Съездда СССР мөселман халыкларының язуын гарәп имлясыннан латин графикасына күчерү турында карар кабул ителә. 1916 да һәм 1925 тә Казанда борынгы төрки ядкәрләрне һәм Алтын Урда тарихи чыганакларын өйрәнә, татарлар турында кульъязмалар һәм этнографик материаллар туплый. Хезмәтләре төрки халыкларның теле, әдәбияты, фольклоры, этнографиясенә, тюркологиянең гомуми мәсьәләләренә һәм тарихына карый. С., төрки телләрнең фонетик үзенчәлекләренә нигезләнеп, аларның классификациясен төзи. Төрки телләрнең төзелешенә карашын, аерым алганда, үзенең грамматик концепциясен «Төрек телләренең классификациясенә кайбер өстәмәләр» («Некоторые дополнения к классификации турецких языков», П., 1922), «Хәзәрләрнең варислары һәм мәдәнияте мәсьәләсенә карата» («К вопросу о наследниках хазар и их культуры», Л., 1924), «Литва татарлары һәм гарәп алфавиты» («Литовские татары и арабский алфавит», Баку, 1926), «Идел-Урал төбәгендә мәдәни һәм этник мөнәсәбәтләр тарихына карата» («К истории культурных и этнических отношений в Волжско-Уральском крае», М., 1927) хезмәтләрендә бәян итә. «Тимер Котлыгъ хан ярлыгына берничә төзәтү» («Несколько поправок к ярлыку Тимур-Кутлуга», П., 1918), «Җучи олысында «пайза»-«байса» турында: Әхмәт хан басмасы мәсьәләсенә карата» («О «пайза»-«байса» в Джучиевом улусе: К вопросу о басме хана Ахмата», Л., 1926), «Туктамыш хан ярлыкларының басмасы һәм тәрҗемәсенә берничә төзәтү» («Несколько поправок к изданию и переводу ярлыков Тохтамыш-хана», Симферополь, 1927) һ.б. хезмәтләре, төрки халыкларның мәдәни һәм тарихи ядкәрләре буларак, Алтын Урда һәм Кырым рәсми документларын анализлауга багышлана. «Җүчи олысы, яки Алтын Урданың әдәби теле» («Литературный язык Джучиева улуса, или Золотой Орды», Истанбул, 1935) хезмәтендә Урта Азиягә хас төрек әдәби теленең Алтын Урда чорындагы үсеше идеясен дәлилли. «Профессор Н.Ф.Катанов — Абакан төрекләреннән беренче галим» («Профессор Н.Ф.Катанов — первый учёный из абаканских турков», Верхнеудинск, 1924), «Казанда егерме көн» («Двадцать дней в Казани», 1925), «Татарстан АССРда туган якны өйрәнү» («Краеведение в Татарской АССР», 1925), «Галимҗан Ибраһимов — татар халкын өйрәнүче галим» («Галимджан Ибрагимов как татаровед», 1929) язмаларында Татарстанда шәркыятьчелек һәм туган якны өйрәнү фәне торышына кыскача характеристика бирә. Рус археол. һәм Рус геогр. җәмгыятьләренең хакыйкый әгъзасы (1908). Репрессияләр чоры корбаны.

Х е з м.: Вариант сказания о Едигее и Тохтамыше, записанный Н.Хакимовым // Тюркол. сборник. 1972. М., 1973; Общий взгляд на возникновение и развитие мусульманско-турецких литературных языков в связи с разговорными наречиями // Советская тюркология. 1973. № 5.

*Әд.:* А ш н и н Ф.Д. Александр Николаевич Самойлович (1880–1938) // Народы Азии и Африки. 1963. № 2; Д м и т р и е в а Л.В. Материалы к описанию рукописного наследия А.Н.Самойловича // Народы Азии и Африки. 1966. № 3.

*Е.Б.Долгов.*

**«САМОЛЁТ»**, Россиядәге пароходчылык компаниясе. 1853 елда Идел елгасы һәм аның Тверь, Рыбинск һәм Ярославль шәһәрләре арасындагы кушылдыкларында пароходлар йөртү максатыннан оештырыла. Гамәлгә куючылары: Россия флотының отставкадагы капитаны В.А. фон Глазенап һәм титуляр советник М.Г.Бехагель фон Адлерскрон. Пароходлар, башлыча, Бельгиянең «Коккериль» з-дында төзелә. Компаниянең 1850 елларда — 20, 1862 дә — 25, 1870 еллар уртасында 38 пароходы («Товарищ», «Дриада», «Курьер», «Быстрый», «Гонец», «Депеша», «Джон Коккериль», «Казань», «Астрахань», «Владимир Глазенап» һ.б.) була. 1880 еллардан Америка пароходлары тибындагы ике палубалы пароходлар («Вера», «Великая княгиня Мария Павловна» һ.б.) файдаланыла башлый; судноларының зур йөк күтәрешлелеге һәм югары тизлеге компаниягә көндәшләре алдында өстенлек бирә. 1912 дә «С.» тарафыннан 937622 сумлык йөк ташыла. 1857 дә «С.» пароходлары Казанга кадәр килә башлый. Түбән Новгородтан Казан аркылы Әстерханга рейслар ясаучы суднолар ике линия тәшкил итә: беренчесе — куәте кимрәк «Самолёт», «Жуковский» пароходлары, икенчесе — Америка тибындагы «Тургенев», «Некрасов», «Пушкин» һ.б. пароходлар (1890 еллар ахыры). «С.» 1918 нең гыйнварында национализацияләнә. Пароходларның күбесе совет елга флотында 1960 еллар башына кадәр хезмәт итә; «Спартак» («Великая княжна Татьяна Николаевна»), «Володарский» («Великая княжна Ольга Николаевна») 1990 га кадәр файдаланыла.

*Әд.:* Пароходное общество «Самолёт»: Очерк 50-летней деятельности. 1853–1903 г. СПб., 1903; Речное судоходство в России. М., 1985.

*В.А.Шагалов.*

**САМО́НОВКА** посёлогы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 45 *км* көньяк-көнбатыштарак, Оша елгасы буенда. 2010 елда 34 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1930 елларда «Прикамский» с-зының Самоновка бүлекчәсе буларак нигез салына. Оештырылган көненнән — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1949 да — 57, 1958 дә — 127, 1970 тә — 65, 1979 да — 113, 1989 да — 63, 2002 дә — 56 кеше.

**САМОРО́ДНОВ** Матвей Михайлович (18.8.1927, Чистай кантоны Берёзовая Грива а. — 21.6.2010, Алексеев р-ны Алексеев штп), агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Тәтеш а.х. техникумын тәмамлый (1967). 1940–83 елларда Алексеев р-нында: «Заветы Ленина» к-зында тракторчы (1943 тән), клуб мөдире (1953 тән), бригадир (1956 дан), «Левашовский» (1963 тән), «Лебединский» (1968) с-зларында бүлек управляющие; «Родина» к-зы рәисе (1968 дән), «Красный Восток» с-зы директоры (1972–83). С. ике хуҗалыкның да үсешенә өлеш кертә. 1972 дә «Родина» к-зында бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 20,9 *ц* га, еллык савым һәр сыердан уртача 2932 *кг* га җитә. «Красный Восток» с-зында С. җитәкче булганда бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 6,5 *ц* га, еллык савым һәр сыердан 243 *кг* га арта; 460 баш мөгезле эре терлек өчен бина, 3000 баш дуңгыз өчен ферма, 6838 $м^2$ торак йорт төзелә. Октябрь Революциясе ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**САМОРУ́КОВ** Рафаэль Станиславович (6.11.1935, Мәскәү — 1.2.2002, шунда ук), балет артисты, педагог, Бурят АССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1989), ТРның халык артисты (1997). 1962 елда Кыргыз хореография уч-щесен (Фрунзе) тәмамлый. 1960–63 тә А.Малдыбаев исем. Кыргыз опера һәм балет театрында балет артисты, 1963–67 дә һәм 1972–79 да — С.Айни исем. Таҗик опера һәм балет театрында (Дүшәнбе), 1967–72 дә һәм 1979–83 тә А.С.Пушкин исем. Горький опера һәм балет театрында балет артисты һәм педагог-репетитор, 1984 тән — Белорус Зур опера һәм балет театрында (Минск), 1986 дан Бурят опера һәм балет театрында (Улан-Удэ) педагог-репетитор. Бер үк вакытта Бурят хореография уч-щесендә укыта. 1989 дан Татар опера һәм балет театры педагог-репетиторы. А.Аданның «Жизель» (1992), П.Чайковскийның «Аккош күле» («Лебединое озеро», 1993), «Йокыга талган күзәл» («Спящая красавица», 1996), «Щелкунчик» (1999), Л.Минкусның «Дон Кихот» (1994, Л.Трембовельская б-н бергә), Ф.Шопен музыкасына «Шопениана» (1998), Ш.Гуноның «Вальпургия төне» («Вальпургиева ночь», 1998) балетларының классик редакцияләрен яңарта.

*Әд.:* Народные артисты СССР, РФ, РТ. К., 2011.

*В.Н.Горшков.*

**САМОСЫ́РОВО** авылы, Казан шәһәренең Совет р-ны карамагында, Казан тимер юл станциясеннән 11 *км* көнчыгыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2008 елда 705 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — яшелчәчелек. Башлангыч мәктәп, китапханә. 1565–67 еллардагы чыганакларда — Самасыр Пүчинкәсе, 17 йөздә Кече Татар Клыкие исемнәре б-н билгеле. Башта халкы Спас-Преображение монастырена карый, 1763 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, бакчачылык, тимерчелек, тәгәрмәч ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.да земство мәктәбе (1893 тә ачыла), җил тегермәне, 15 кә якын тимерчелек остаханәсе, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1127,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кощаково волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында, 2007 нең 28 декабреннән Казанның Совет р-нында. Халык саны: 1646 да — 94, 1782 дә — 91 ир-ат; 1859 да — 325, 1897 дә — 501, 1908 дә — 520, 1920 дә — 669, 1926 да — 781, 1949 да — 600, 1958 дә — 712, 1970 тә — 746, 1989 да — 596, 2002 дә — 576 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**СА́МОЧКИН** Анатолий Васильевич (1.5.1914, Сембер губ. Буа ш. — 15.5.1977, Ярославль өлкәсе Рыбинск ш.), Сов. Союзы Герое (27.3.1942), подполковник. Ульянов очучы-инструкторлар мәктәбен (1939), проф. Н.Е.Жуковский исем. Хәрби-һава инженерлар академиясен (Мәскәү, 1946) тәмамлый. Рыбинскида заводта, авиация клубында инструктор булып эшли. 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 289 нчы якын араларга оча торган бомбардировщиклар авиациясе полкы пилоты (40 нчы армиянең 63 нче катнаш авиация дивизиясе). С. Көньяк-Көнбатыш фронтның һава армиясе составында 1942 нең гыйнварына, дошманның стратегик объектларын, сугышчыларын һәм техникаларын бомбага тоту өчен, 115 сугышчан очыш ясый. 1961 дән запаста, Түбән Новгород шәһәрендә яши. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



А.В. Самочкин.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**САМУИ́ЛОВ** Феофан Дмитриевич (23.6.1928, Чуаш АССР Янтык р-ны Уразкассы а.), үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (1969), проф. (1970), ТАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1990, 1997). ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы (2007). Чуаш пед. ин-тын тәмамлый (1950). 1951–63 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Биология ин-тында. 1963 тән Казан аграр ун-тында, ботаника һәм үсемлекләр физиологиясе каф. мөдире (1970–98). Хезмәтләре үсемлекләрнең су алмашу физиологиясен һәм тотрыклылыгын өйрәнүгә, агроэкологиягә карый. Авыр су һәм югары сизгерлекле физик алымнар: ЯМР, ЭПР, гамма-резонанс һәм диэлектрик спектроскопия кулланып, С. күзәнәкләрдә төрле су фракцияләренең хәрәкәтчәнлеген һәм тиз алмашучанлыгын, үсемлекләр б-н тышкы тирәлек арасында суның үзара ике яклы алмашуын билгели. Үсемлекләрдә су алмашы турындагы элеккеге осмотик күзаллаулардан аермалы буларак, үсемлекләрдә су алмашу һәм су халәтенең аларның метаболизмына, биоэнергетик процессларына бәйле булуын күрсәтә. Үсемлекләрнең метаболизмына тәэсир итү юлы б-н (чәчү алдыннан орлыкларны эшкәртүдә физиол. процессларны тизләтү, минераль туклануны көйләү һ.б.) аларның әйләнә-тирәнең тискәре шартларына (корылык, су басу, түбән темп-ра һ.б.) тотрыклылыгын күтәрү мөмкинлеген ачыклый. Тикшеренү нәтиҗәләре а.х. культураларының тотрыклылыгын күтәрү һәм су режимын оптимальләштерү технологияләрен эшләүнең теоретик нигезләрен киңәйтә. С. җитәкчелегендә Урта Идел буе һәм Оренбург Урал алды төбәкләренең урман-дала шартларында сабан бодаеның 40 тан артык сортына экологик-физиол. тикшеренү үткәрелә, алар нигезендә селекция эшләре өчен беренчел форманы сайлау буенча күрсәтмәләр әзерләнә; респ-ка өчен яңа культуралар: кукуруз, шикәр чөгендере, рапс игүнең төньяк зонадагы физиол. үзенчәлекләре тикшерелә. «Үсемлекләрнең су алмашы һәм минераль тукландыру буенча практикум» («Практикум по минеральному питанию и водному обмену растений», СПб., 1996) уку дәреслеге авторларының берсе. Медальләр, СССР ФА Президиумы, СССР Югары һәм махсус урта белем бирү министрлыгының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Водный обмен и состояние воды в растениях в связи с их метаболизмом и условиями среды. К., 1972; Водный обмен растений. М., 1989 (автордаш); Спин — решёточная релаксация протонов воды в растительных и животных клетках // Биофизика. 2012. Т. 57, вып. 4 (автордаш).

**САМУИ́ЛОВ** Яков Дмитриевич (26.6.1946, Чуаш АССРның Янтык р-ны Уразкассы а.), химик-органик, химия фән. д-ры (1985), проф. (1995), ТРның атказ. химигы (2006). 1969 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, органик кушылмаларның структурасын өйрәнү фәнни-тикшеренү лаб-ясенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. 1990 нан Казан технол. ун-тында, Эластомерлар эшләү үзәге директоры урынбасары, 1995 тән ясалма каучук технологиясе каф. профессоры. Хезмәтләре диен синтезына, югары молекуляр кушылмаларны өйрәнүгә карый. С. төсле фотомомент эшчәнлегенең, сополимер күкерт табуның принципларын эшли. Аддентларның донор-акцептор үзлекләрен һәм аларның $[4_\pi+2_\pi]$-цикл кушу реакцияләрендә активлыгын билгели. Югары дәрәҗәдә саф гәрәбә һәм фумар к-таларын синтезлау алымын эшләүдә, аларны азык һәм дару кушылмалары ясау өчен җитештерүгә кертүдә катнаша (Варна шәһәрендәге Халыкара күргәзмәдә алтын медаль, Болгария, 1992). Чиксез кушылмалар озонолизы механизмын тикшерә, өчле этиленпропилен каучуктан бәрелүгә чыдам полистирол, термоэластопластлар таба. Алкилароматик кушылмаларны гидроперекись ачыту катализаторларын тәкъдим итә. Изоцианатларның спиртлар б-н каталитик булмаган реакциясе механизмын өйрәнү нәтиҗәләре полиуретаннар табу процессы б-н идарә итүдә кулланыла. Яңа типтагы полимер тио-материаллар — полиэфируретантиоллар синтезлауның бер реакторлы калдыксыз алымын, ш.у. стереоүзгәлекле цис-полибутадиен каучук табуның газ фазалы ысулын эшли (фәнни ясалма эшкәртмәләре Казан каучук з-дында, РФнең азык-төлек сәнәгате пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән). Уйлап табуга 40 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Реакционная способность органических соединений. К., 2003 (автордаш); Межфазный катализ. К., 2005 (автордаш); Олигомеры на основе тиодигликоля // Журн. прикладной химии. 2007. Т. 80, № 12 (автордаш).

**САН** (лингв.), 1) сүз төркеме, предметларның санын, микъдарын белдерә. С.ның аерым төркемчәләре ш.у. предметларның саналу тәртибен, җыелма күплеген, якынча һәм төгәл санын, аларны тигез өлешләргә бүлүне белдерә. Татар телендә С.ны түбәндәге төркемчәләргә бүлеп өйрәнәләр: микъдар С.ы, тәртип С.ы, җыю С.ы, бүлем С.ы, чама С.ы. Микъдар С.ы бернинди өстәмә кушымчалар алмый һәм предметның санын, микъдарын белдерә (алты китап, унбиш бала, утыз көн). Кайбер микъдар С.нары башка мәгънәләрдә дә кулланылырга мөмкин. Бу очракта аеруча бер, биш, җиде, кырык саннарын билгеләп үтәргә кирәк. Хәзерге татар телендә бу саннар кергән әйтемнәр һәм тотрыклы сүзтезмәләр шактый. Алар билгесез күплек мәгънәсен белдерәләр: биш былтыр, җиде юл чаты һ.б. Ярты, чирек сүзләре дә микъдар С.нарына керә. Вакланма С.нар да микъдар С.нарына кертеп карала: икедән өч, уннан бер. Исем б-н янәшә килгәндә, микъдар С.нары килеш, тартым, сан б-н төрләнми. Бу очракта С. б-н ачыкланган исем, ягъни саналмыш берлек санда килә: өч китап, мең китап. Составы ягыннан микъдар С.ы гади (бер, ике), кушма (унбер, унбиш) һәм тезмә (егерме бер, утыз биш) С.нарга бүленә. Тәртип С.ы микъдар С.ына -ынчы/-енче, -нчы/-нче кушымчалары ялганып ясала һәм предметларның яки күренешләрнең сан буенча тәртибен белдерә (беренче көн, алтынчы сыйныф). Җыю С.ы, С. нигезенә -ау/-әү кушымчалары ялганып,



А.Г.Сандецкий.

С.ның беренче унлыгы (1 дән 10 га кадәр) җирлегендә ясала һәм предметларны сан буенча бергә җыйнап әйтүне белдерә. Җыю С.нары фигыльгә ияреп киләләр һәм теге яки бу күренештә катнашучы затларның (предметларның) җыелма күплеген күрсәтәләр (өчәү бардык), өстәмә рәвештә -лап/-ләп, -лашып/-ләшеп кушымчалары да алырга мөмкин (икәүләшеп эшлибез). Бүлем С.ы микъдар С.ына -ар/-әр, -шар/-шәр кушымчалары ялганып ясала һәм төрдәш предметларны сан буенча тигез өлешләргә бүлүне белдерә (алтышар алма). Чама С.ы -лап/-ләп кушымчалары ялганып ясала һәм предметларның якынча санын белдерә (унлап кеше). Чама С.ы үзара якын торган саннарны кабатлау юлы б-н дә (биш-алты сүз), ш.у. -лар/-ләр, -нар/-нәр кушымчалары ялганып та ясала ала (уннарча ел). 2) грамматик категория, предметларның санын, күләмен белдерә. Берлек һәм күплек сан формалары бар. Татар телендә С. категориясе исемнәргә (китап — китаплар, урман — урманнар), исемләшкән сыйфатлар һәм рәвешләргә (белемле — белемлеләр), исемне алыштырып килүче күрсәтү алмашлыкларына (бу — болар) хас. Берлек С.ның морфологик күрсәткечләре юк, ягъни исем кушымчасыз, ноль формада килә һәм предметның бер генә булуын күрсәтә. Күплек С. сүзнең нигезенә ялгана торган махсус кушымчалар б-н белдерелә. Күплек С. кушымчасының 4 төре билгеле: -лар — калын нигезгә (атналар, туплар), -ләр — нечкә нигезгә (тәрәзәләр, ишекләр), -нар — борын авазына беткән калын нигезгә (урамнар, каеннар), -нәр борын авазына беткән нечкә нигезгә (киемнәр, төннәр) ялгана. Татар телендә берлек С.да гына кулланылучы исемнәр бар. Аларга җыйма исемнәр (халык, каенлык), абстракт мәгънәле исемнәр (үсеш, батырлык), бүленмәгән күплек, бербөтенлек мәгънәсен бирүче матдәлекне белдергән исемнәр (сөт, шикәр) керә. Парлы предметларны яки ике өлештән торган предметларны белдергән сүзләр дә, гадәттә, берлек С.да килә: оек, күзлек, кайчы. Сан б-н ачыкланган исемнәр берлек С. формасында гына була ала: биш атна, егерме биш студент. Предметларны гомумиләштереп, җыйма мәгънәдә биргән исем ш.у. еш кына берлек С. формасында килә: алма сатып алдым, кыяр үстердем. Чынбарлык күренешләренең атамалары да бары берлек сан формасында гына кулланыла: ай, кояш. Татар телендә барлык исемнәр дә берлек С. формасына ия. Күплек С. кушымчасы алган кайбер исемләшкән сүзләр генә (яшьләр, кызыллар) берлек С.дагы исем б-н белдерелә алмый.

*Әд.:* Т у м а ш е в а Д.Г. Хәзерге татар теле морфологиясе. К., 1978; Татар грамматикасы: Морфология. М.–К., 2002. Т. 2; Х и с а м о в а Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006.

*Ф.М.Хисамова.*

**САНАМЫ́Ш**, халык авыз иҗаты жанры; бала-чага уеннарында көйләп әйтелә торган ритмик кыска шигырьләр. Санау системасы барлыкка килгән вакытларга барып тоташа; «бәхетле» һәм «бәхетсез» саннарның тылсымлы үзенчәлекләренә ышану б-н бәйле. Күләмнәре ягыннан татар С.лары кыска (3–5 шигъри юл) һәм озын (30–35 юл) булалар. Авазлар аһәңлелегенә, күпмәгънәлелеккә һәм тәрҗемә ителми торган сүзләр уенына нигезләнә («Бер тай, ике тай, өч тай, дүрт тай — чыгып тай!», «Ыргадан, мыргадан, мәче йөри елгадан. Амыр, помыр. Дәсәтбикә, Сөтбикә!» һ.б.).

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Балалар фольклоры. К., 1993; Татар балалар фольклоры. К., 1999; Словарь литературоведческих терминов. М., 1974.

*Ф.И.Урманчеев.*

**САНА́ЧИН** Павел Алексеевич (12.7.1918, Казан губ., Мамадыш өязе Бөрсет а. — 5.5.1984, Казан), архитектор. РСФСРның атказ. архитекторы (1975). 1939 елда Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тын тәмамлый. 1946–51 дә ТАССР МС Архит-ра эшләре идарәсенең архит-ра-проектлау остаханәсе баш архитекторы, 1953 тә Казан өлкә башкарма ком-тының архит-ра эшләре бүлеге башлыгы. 1954 тән «Татпроект» проектлау конторасы проектларының баш архитекторы, 1962 дән ТАССР МС каршындагы Төзелеш һәм архит-ра эшләре идарәсе башлыгы. Бер үк вакытта, 1952–62 дә, Казан төзүче инженерлар ин-ты укытучысы. 1979–84 тә ТАССР Дәүләт төзелеш ком-ты рәисе, 1958–62 дә Архитекторлар берлегенең Татарстан оешмасы идарәсе рәисе, 1961–64 тә СССР Архитекторлар берлегенең Үзәк идарәсе әгъзасы.



П.А.С а н а ч и н. ТАССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең төп бина комплексы. 1957.

С. проектлау эшчәнлеге б-н, башлыча, Г.И.Солдатов б-н берлектә шөгыльләнә (ген. планнар, детальле планлаштырулар, төзелешләр проектларының иң әһәмиятлеләре 1950 елларның 1 нче яртысына — сугыштан соңгы неоклассицизм һәм совет чоры ампирына туры килә). Яшел Үзән, Бөгелмә, Лениногорск, Әлмәт, Чистай (Р.М.Мортазин б-н автордаш), Чаллы (Үзәк фәнни-тикшеренү һәм торак йортлар проектлау ин-ты б-н берлектә), Азнакай шәһәрләренең, Питрәч р-ны Кокушкино авылының ген. проектын һәм төзелеш проектын эшләүдә катнаша. Казандагы Дербышки бистәсе, 237 нче з-д карамагындагы Соцгород, «Теплоконтроль» һәм В.И.Ленин исем. з-д кварталлары, Татарстан һәм Пушкин урамнары; ВКП(б) өлкә ком-ты бинасы (Бобруйск шәһәрендә кабатлана), он тарту комб-ты, «Теплоконтроль» з-ды торак йортлары; Дербышки бистәсендәге 2–3 катлы йортлар сериясләре; Казанның Татарстан урамындагы беренче 9 катлы йортлары, «Казэнерго» бинасы (хәзерге «Татэнерго» ААҖ; И.А.Вәлиев б-н берлектә), Казан вет. ин-ты комплексы һәм аерым биналары, ТАССР ВДНХсы комплекслары (төп павильонның ген. планы һәм проекты), Үзәк стадион (А.А.Спориус һәм О.И.Берим б-н берлектә), Үзәк универсам (С.П.Галанина б-н берлектә), КПССның Татарстан өлкә ком-ты Сәяси мәгариф йорты (хәзер ТР ФА бинасы; А.А.Спориус б-н берлектә) һ.б. проектларның авторы. 1968–84 тә РСФСР МСның Әдәбият, сәнгать һәм архит-ра өлкәсендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясе әгъзасы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 3 нче дәрәҗә Богдан Хмельницкий, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, ике Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәрендәге яр буе һәм Казандагы бер тыкрык аның исемен йөртә.

*С.П.Саначин.*

**САНДЕ́ЦКИЙ** Александр Генрихович (17.8.1851–1918, Мәскәү), хәрби эшлекле, инфантерия генералы. Дворяннар нәселеннән. 2 нче Константин хәрби уч-щесен (С.-Петербург, 1871), Ген. штабның Николай академиясен (С.Петербург, 1878) тәмамлый. 1871 елдан хәрби хезмәттә. 1878–80 дә Көнбатыш Себер хәрби округы, 1880–83 тә Омск хәрби округы, 1885–87 дә 2 нче Кавказ армия корпусы штабларында. 1883–85 тә Җидесу өлкәсе (Урта Азия) гаскәрләре командующие каршында штаб-офицер. 1887–90 да Карс кальгасы (Кавказ арты) штабы, 1890–95 тә пехота һәм гренадерлар дивизияләре штабы, 1895–99 да Байкал аръягы гаскәрләре штабы башлыгы. 1899–1904 тә бригада командиры, 1904–06 да пехота дивизиясе башлыгы, 1906–07 дә гренадерлар корпусы командиры. 1907–12, 1915–17 дә Казан хәрби округы гаскәрләре командующие. 1912 дән Хәрби совет әгъзасы (С.-Петербург). 1914–15 тә Мәскәү Хәрби округы гаскәрләре командующие. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Казанда кулга алына, отставкага җибәрелә. Мәскәүдә яши. Бөтенроссия гадәттән тыш комиссиясе карары нигезендә атып үтерелә.

*Әд.:* Список генералам по старшинству на 1914 год. СПб., 1914; З а л е с с к и й К.А. Кто был кто в Первой мировой войне. М., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**САНДЕ́ЦКИЙ САРАЕ́**, к. *Казан хәрби округы командующие йорты.*

**САНДУГАЧЛА́Р** (Luscinia), миләш чыпчыгысыманнар семьялыгыннан кошлар ыругы. 20 гә якын төре билгеле, Евразиядә һәм Төньяк-көнбатыш Африкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади яки көн-

чыгыш С.ы (L. luscinia) барлык районнарда да очрый. Яфраклы һәм катнаш урманнарда, бакча, паркларда, елга үзәннәрендә яши. Күчмә кош, апрель–майда оя кору урыннарына килә. Гәүдәсенең озынлыгы 17–19 *см*, авырлыгы 22–32 *г*, ана кошлар аталарыннан берникадәр кечерәк. Аркасы коңгырт-зәйтүнсыман, корсагы соргылт, койрык өсте җирәнрәк төстә; ата һәм ана кошларның төсләре бертөрле. Күзләре зур. Оясын җирдә яки



Гади сандугач.

черек агач төпләрендә ясый. 4–6 яшькелт йомырка сала. Бөҗәкләр, үрмәкүчләр, әкәм-төкәмнәр, көзен җимешләр һәм орлыклар б-н туклана. Сандугач сайравы сызгыру, гөрелдәү һәм чутылдау тавышларыннан (24 «борылмага» кадәр) тора. Кышларга сентябрьдә очып китә.

**САНИТАРИ́Я ТЕ́ХНИКАСЫ**, к. *«Сантехприбор»*.

**«САНИЯ́»**, опера, композиторлар Г.С.Әлмөхәммәдов, В.И.Виноградов һәм С.Х.Габәшинең 3 күренешле әсәре. Г.С.Әлмөхәммәдов либреттосы. Татар һәм башкорт музыкасы традицияләре нигезендә иҗат ителгән опера жанрындагы беренче әсәр. Патриархаль гаилә әхлагына каршы торган сәүдәгәр кызы Сания һәм укытучы Зыяның фаҗигале мәхәббәт тарихы. Премьерасы 1925 елның 25 июнендә Татар акад. театрында була; дирижёры А.А.Литвинов, режиссёры Ә.А.Хисамов, балетмейстеры Ю.А.Муко, төп рольләрдә — З.Г.Байрашева, Г.С.Әлмөхәммәдов, С.Х.Габәши. 1926 ның 16 гыйнварында реж. Г.С.Айдарскийның яңа постановкасы тәкъдим ителә. Сания ролен С.С.Садыйкова башкара, бу роль авторлар тарафыннан махсус аның өчен языла. Спектакльне рәссам П.Т.Сперанский бизи, оркестр тынлы һәм бәрмә музыка уен кораллары б-н көчәйтелә, балетм. Ю.А.Муко биюләрне яңадан эшли. Спектакль 1927 дә реж. Г.Г.Девишев тарафыннан яңадан куела (дирижёр А.А.Литвинов, балетм. Ю.А.Муко; Сания ролендә — З.Г.Байрашева, Зыя ролендә — Г.С.Әлмөхәммәдов). 1930 да «С.» 2 тапкыр сәхнәгә куела: гыйнварда (дирижёр С.Җ.Сәйдәшев, реж. З.Г.Солтанов, балетм. Г.Х.Таһиров, Сания ролендә — Л.Гаврилова, Р.Садыйкова, Зыя ролендә — Г.С.Әлмөхәммәдов, С.Х.Айдаров) һәм ноябрьдә (реж. К.Тинчурин, Сания ролендә — С.С.Садыйкова, калганнары – шул ук башкаручылар).

*Әд.:* А й д а р с к и й  Г. Первая татарская опера // Слово искусства. 1925. № 6; Газиз Альмухаметов и Султан Габаши в Казани: Материалы и документы. Уфа, 1995; Султан Габаши: Материалы и исследования. К., 2000.

**САНКТ-КАТАРИ́НА КИРХАСЫ́**, к. *Изге Екатерина кирхасы*.

**САНКТ-ПЕТЕРБУ́РГ** (1914–24 елларда — Петроград, 1924–91 дә — Ленинград), федераль шәһәр, Россия Федерациясе субъекты, *Ленинград өлкәсе* үзәге; Россиянең, Мәскәүдән кала, иң зур сәнәгать, фән һәм мәдәният үзәге. Нева елгасының Фин култыгына койган урынында һәм Нева дельтасы утрауларында урнашкан. Халкы — 5131942 кеше (2013). 2010 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 31 мең (1926 да — 7,3 мең, 1939 да — 31,5 мең, 1959 да — 27,3 мең, 1970 тә — 33,1 мең, 1989 да — 43,9 мең, 2002 дә — 35,6 мең) кеше. С.-П.та татарлар аңа нигез салынганнан бирле (1703 тән) яшиләр. Татар җәмгыяте, башлыча, Казан, Түбән Новгород, Касыйм, Пенза һ.б. җирләрдән шәһәр төзергә килүчеләрдән оеша. Татарлар башта Петропавел крепосте янындагы Татар (1732 дән — Зур һәм Кече Никольская, хәзер — Зверинская) урамына урнаша. 18 йөзнең 1 нче чирегендә С.-П.та Татар бистәсе (к. *Татар бистәләре*) оеша, 1827 дә мөселман зираты (хәзер Волков зиратының татар өлеше) рәсмиләштерелә. Шәһәрнең башкала статусы аңа аерым дәрәҗә өсти. Монда Россия империясендә яшәүче татарлар һ.б. халыклар яшәешен билгеләүче югары хөкүмәт учреждениеләре урнаша. 1785 тә *Азия басмаханәсе* оештырыла, анда татар һәм кырым-татар телләрендә кануннар җыентыгы басыла. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында Петербург адмиралтействосы верфенә Урта Идел буе *лашманнары* әзерләгән корабль ясауга яраклы агач материаллар килә. 19 йөз уртасында Россиянең төрле төбәкләреннән килүче татарлар С.-П.та берничә зур җәмәгать-мәхәллә оешмасын: Мәскәү өлешендә — Казан (Вознесенский, Измайлов, Забалканский проспектлары р-нында), Адмиралтейство өлешендә — Касыйм (Мойка, Гороховая, Пушкинская урамнары, Крюков каналы, Нева проспекты), Түбән Новгород (Загородный проспекты читендәге Пять углов янында) оешмаларын төзи. 1867–80 елларда шәһәрдә *«Бикбулатовның С.-Петербургта Касыйм татарларына ярдәм итү җәмгыяте»* эшли. 1869 да — 2 мең, 1881 дә — 2,7 мең, 1890 да — 3,5 мең, 1910 да 7,3 мең татар яши. Моннан тыш берничә мең татар С.-П.тагы империя гвардия частьларында һәм Кронштадт шәһәрендәге Балтыйк флоты корабльләрендә хезмәт итә. Татарларның төп шөгыле — сәүдә (бигрәк тә, ваклап, ит һәм балык сату), һөнәрчелек (күн һәм тире эшкәртү), олаучылык. 19 йөзнең 2 нче яртысында төзүчеләр һәм завод-фабрикада эшләүчеләр саны арта башлый, күп кенә татарлар көнкүреш хезмәте күрсәтү өлкәсендә (официант, урам себерүче, кучер, ат караучы, кибетче һ.б.) эшли. 20 йөз башында Петербург татарлары Николай, Царское Село, Варшава һәм Балтыйк тимер юлларында ресторан һәм буфетлар, шәһәрнең төрле районнарында берничә зур ресторан (Нева проспектында — «Крестовский сад», Кармыш рестораны, Николай вокзалы рестораны; Яңа Авылда (Новая Деревня) — «Сәмәрканд» һ.б.), кибетләр, чәйханә, арендага бирелүче йортлар тоталар. 1910 да С.-П.та 4: Тверь, Мәскәү, Чиләбе, Кронштадт мөселман мәхәлләсе; 1913 тә Төп җамигъ мәчет (архит-ра истәлеге; 2003 тә реставрацияләнә); төрле елларда 6 шар мәктәп эшли. Мөселманнарның танылган җитәкчесе зур галим һәм дин эшлеклесе Г.*Баязитов* була. 1905 тән соң шәһәр Россия татарларының иҗтимагый-сәяси үзәгенә әверелә. Монда Икенче (1906) һәм Дүртенче (1914) *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары*, *Россия мөселманнарының вакытлы мәркәз бюросы* (1917; *«Известия временного центрального бюро российских мусульман»* басма органы), *Бөтенроссия мөселманнары Милли Шурасы* (1917), *Россия мөселман җәмәгать оешмаларының мәркәз (үзәк) комитеты* (1914–17) эшли. Татар телендә — *«Нур»* (1905–14), *«Өлфәт»* (1905–07), *«Дума»* (1907), *«Ил»* (1913–14), *«Милләт»* (1913–15), *«әл-Мөнбәр»* (1917–18); гарәп телендә *«әт-Тилмиз»* (1906–07); рус телендә *«В мире мусульманства»* (1911–12), *«Мусульманская газета»* (1912–14) г-талары; *«Нәҗат»* (1907) (татар телендә), *«Мир ислама»* (1912–13) (рус телендә) ж-ллары нәшер ителә. Татарча әдәбият *«Әманәт»* нәшрияты һәм басмаханәсендә, *Бораганский И.М. басмаханәсендә*, *Максутов М.А. басмаханәсендә*, *«Өлфәт» басмаханәсендә* (1906–07) басыла. *Р.Ибраһимов* «*Миръат*» китаплар һәм брошюралар сериясен нәшер итә. *Петербург мөселманнары арасында мәгърифәт тарату җәмгыяте* (1908–17), *Лигово станциясендә мөселманнар хәйрия җәмгыяте* (1914–17), мөселманнарның *«Ислам вә мәгариф»* мәдәни-агарту һәм хәйрия җәмгыяте (1916–18), *Польша-Литва татар студентлары түгәрәге* (1907–11), *«Татар учагы»* студентлар түгәрәге (1915–16) эшли. 1910 да С.-П.та *«Идел буе төбәгендә мөселман татарлар йогынтысына каршы чаралар билгеләүче махсус киңәшмә»* уздырыла. 1918 дә Петроградта Мөселман соц. (1918 нең июненнән — коммунистик) ком-ты, *Үзәк мөселман хәрби коллегиясе* оештырыла. 20 еллар башындагы *ачлык* чорында (1921–22) Идел буеннан китерелгән татар балалары өчен ятимнәр йорты эшли. *«Чулпан»* (1918–19), *«Шималь ягы»* (1918), *«Ярлы халык»* (1918), *«Кызыл Шималь»* (1918–21), «Ленинград эшчесе», «Кызыл портчы» г-талары чыга. 1928–31 дә шәһәрдә *Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте* эшли. 1937 гә кадәр 4 татар мәктәбе, 2 татар театры, Шәрекъ һәм Татар мәгърифәт йортлары, төрле клублар була. Бөек Ватан сугышы чорында Ленинградның күп кенә зур галимнәре (акад. А.А.*Гринберг*, СССР ФАнең мөхбир әгъзасы С.Н.*Данилов* һ.б.), Казанга күчерелеп, югары уку йортларында һәм фәнни учреждениеләрдә эшлиләр. Ленинград тирәсендәге сугышларда һәм блокаданы өзүдә күп кенә татарлар һәм татарстанлылар (ш.и. Сов. Союзы Геройлары Г.Ә.*Баһаветдинов*, А.Х.*Вәлиев*, Ф.Г.*Заһидуллин*, Н.А.*Козлов*, И.М.*Маннанов*; Дан орденының тулы кавалерлары З.М.*Арсланов*, М.Н.*Скрементов*) батырлык күрсәтә. Ленинград фронтының сәяси идарәсе татар телендә *«Ватанны саклау-*

*да*» г-тасын нәшер итә. 1968–73 тә Ленинград театр, музыка һәм кинематография ин-тында Татар студиясе эшли. 1987 дә шәһәрдә М.Җәлил исем. Татар мәдәниятен яратучылар клубы оештырыла, ул 1989 да — Ленинград татар мәдәнияте үзәге, 1992 дә «Нур» (2000 нән — «Нур-Плюс») татар мәдәни җәмгыяте итеп үзгәртелә. Татар милли-мәдәни автономиясе (1997 дән; рәисе — Н.Г.Кикичев), С.-П. һәм Ленинград өлкәсендә ТРның Даими вәкиллеге (1996; җитәкчесе — Ш.К.Әхмәтшин), «Чишмә» татар-башкорт җәмгыяте (1995), «Петербург Сабантуе» (1998), милли мәдәниятне торгызу һәм үстерү (1998) фондлары, «Ак калфак» Хатын-кызлар ассоциациясе ф-лы (Казан) — «Ак калфак-Нева» (2001) эшли. «Шатлык» (1994), «Ак калфак», «Ак төннәр» татар балалар фольклор ансамбльләре, «Болгар иле» һәм «Оседлое кочевье» (1987) рәссамнар төркемнәре була. 1990 нан рус-татар «Нур» г-тасы яңадан чыга башлый. 1991 дә «*Татарт*» беренче гомумтатар сынлы сәнгать күргәзмәсе уздырыла. Дәүләт Эрмитажында татар тарихына кагылышлы 7 меңләп мәдәният ядкәре (ш.и. «Кубрат хан хәзинәләре» тупланмалары) саклана. Россия этнография музее фондларында татар халкының 4 меңнән артык матди мәдәният эшләнмәләре (киемнәр, бизәнү әйберләре, көнкүреш кирәк-яраклары) исәпләнә, РФА китапханәсендә татар китаплары тупланмасы («Казан фонды») саклана. Татарстан б-н С.-П. арасында тыгыз фәнни-мәдәни бәйләнешләр урнаша. Казан мотивлары Г.Р.*Державин* әсәрләрендә чагылыш таба. Россиянең күп кенә зур галимнәре төрле елларда Казан һәм Петербург ун-тларында (Н.Н.*Бекетов*, И.Н.*Березин*, В.П.*Васильев*, Н.Н.*Зинин*, Г.К.*Казимбәк*, А.О.Ковалевский, А.Я.*Купфер*, П.Ф.*Лесгафт*, Ф.Я.*Чистович*), Хәрби-мед. академиясендә (В.М.*Аристовский*, В.М.*Бехтерев*, А.А.*Вишневский*, В.С.*Груздев*, А.Я.*Данилевский*, В.П.*Осипов*, В.В.*Пашутин*, В.Н.*Тонков* һ.б.) эшлиләр. *Шәрекъ бүлеге* 1855 тә Казаннан бирегә күченү б-н, шәркыятьчеләрнең Петербург мәктәбе Россиядә иң алдынгыларның берсенә әйләнә. С.-П.та тарихчы, филолог, педагог Х.*Фәезханов* яши һәм эшли, Петербургның шәркыятьче галиме Б.А.*Дорн* 1801–66 да Казанда нәшер ителгән татар китапларының библиографиясен төзи. Арх. И.Е.Старов проекты буенча Казанда Казан Богородица хатын-кызлар монастыреның төп храмы төзелә; И.П.*Бессонов*, Л.К.*Хрщонович*, Я.М.*Шелковников* Петербург архит-ра мәктәбе традицияләрен үстерәләр. Рәссам В.Г.*Худяков* татар тарихы һәм көнкүреше темаларына картиналарын багышлый. Казан губернасы терр-ясендә археол. казу эшләре б-н А.А.*Спицын* җитәкчелек итә. Агроном-селекционерлар Ф.Х.*Бәхтиев*, Ш.Г.*Бексиев*, Р.Һ.*Макашева*, Ә.Т.*Мещеров*; актёрлар Э.Г.*Җиһаншина*, А.З.Либабов; балет артистлары Т.Б.*Балтачиев*, Н.В.*Балтачиева*, Р.Х.*Нуриев*; астроном Ш.Г.*Шәрәф*; библиограф Э.К.*Сәгыйдова*; дин галиме М.*Бигиев*; хәрби башлыклар Ф.М.*Әхмәтвәлиев*, М.М.*Әһлиуллин*, В.Р.Акчурин, В.А.*Бәдертдинов*, Р.И.*Галимов*, М.Җ.*Искәндәров*, И.И.*Исламов*, М.Х.*Колахмәтов*, Ю.М.*Хәлиуллин*, Р.М.*Йосыпов*; шәркыятьче галимнәр Ә.Б.*Халидов*, Г.Т.*Таһирҗанов*; дирижёр Р.Ә.*Мартынов*; геолог Р.С.*Сәхибгәрәев*; геофизик Л.Р.*Рәкыйпова*; нәкышьчеләр Ф.Г.*Әминов*, С.М.*Бәхтиярова*, Р.А.*Гыйләҗев*; журналист Р.Х.Теляшов; тарихчылар З.Ш.*Янгузов*, В.С.*Ягъя*; математик И.Г.*Ибраһимов*; табибләр Р.Г.*Имангулов*, Ф.Х.*Кутушев*, Г.М.*Рафиков*, А.Ф.*Урманчиева*, Р.Г.*Хантимеров*, Р.Х.Яфаев; Олимпия чемпионы Р.И.*Сафин*; оптик Д.Д.*Максутов*; җырчы А.Н.*Әсәдуллин*; педагог һәм археограф С.А.*Алимов*; педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Г.*Буби*, дин эшлеклеләре Б.Н.Исаев, Ж.Н.Пончаев; скрипкачы И.М.*Аитов*; сынчы М.К.*Байкиев*; химик Г.А.*Шаһисолтанова*; механика өлкәсендәге галим Ф.З.*Байбурин*; театр һәм кино рәссамнары Р.Р.*Доминов*, В.С.*Рәхмәтуллина*; гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы М.*Таҗибаев*; философлар Р.Х.*Бариев*, К.Н.*Хәбибуллин*; икътисадчылар Н.Ф.*Газизуллин*, Р.Г.*Исләев*, Р.З.*Сәйфуллин*; электротехник М.Х.*Макашев*; юрист һәм җәмәгать эшлеклесе Р.Ф.*Исмәгыйлев*; тел галиме Ү.Ш.*Байчураның* тормышлары һәм хезмәт эшчәнлекләре С.-П. б-н бәйле. 1996 да ТР б-н С.-П. арасында икътисад, фән-техника һәм мәдәният өлкәсендә хезмәттәшлек итү турында килешүгә кул куела. 2003–05 елларда С.-П.ның — 300, Казанның 1000 еллыгына багышланган берничә уртак икътисади һәм мәдәни чара уздырыла (ш.и. С.-П.та — Казан урамы, Казанда Петербург ур. яңартып төзелә). «Казан Кремле» тарих-архит-ра һәм сәнгать музей-саклаулыгының «Эрмитаж» үзәгендә Дәүләт Эрмитажы фондларыннан экспонатлар һәм тупланмалар даими куела. 2006 да С.-П.та шагыйрь Г.Тукайга һәйкәл ачыла.

*Әд.:* А м и н о в Д.А. Татары в Санкт-Петербурге: Ист. очерк. СПб., 1994; Г а ф у р о в а А.Ш. Татарская газета «Нур» в Санкт-Петербурге и её основатель Атаулла Баязитов. СПб., 2003; Т е л я ш о в Р.Х. Татарская община Санкт-Петербурга. СПб., 2003.

*Ш.К.Әхмәтшин, А.И.Ногманов.*

**САНКТ-ПЕТЕРБУ́РГ ҖАМИ́ГЪ МӘЧЕТЕ́**, дини архит-ра истәлеге. Петербургта беренче мөселман мәхәлләсе 1822 елда, икенчесе 1870 тә ачыла; икесе дә вакытлыча файдаланугa алынган бүлмәләрдә эшләп килә. Мәчет төзү өчен рөхсәт алырга тырышу озак еллар буе нәтиҗәсез кала бирә. Мәсьәлә 1906 да Бохара әмире Сәед Галим ханның үтенеченнән соң хәл ителә; ул мәчет төзелеше өчен җир кишәрлеге сатып ала һәм төзелешкә кирәкле акчаның яртысына якынын бирә (калганын Россия мөселманнары җыя). Проект сайлау конкурс нәтиҗәләре буенча ачыклана, арх. Н.В.Васильевның С.С.Кричинский (Россиядә бердәнбер мөселман архитектор) һәм А.И. фон Гоген тарафыннан берләштереп төгәлләнгән 2 проекты җиңеп чыга. Петроград ягында Кронверк проспекты б-н Атлар тыкрыгы почмагында урнашкан. Үзәгендә, биек цилиндрик барабан өстендә, гөмбәз (39 *м*), төньяк фасадының як-ягында 2 биек манара калкып торган (48 *м*), планда 45×32 *м* зурлыктагы турыпочмаклы бина. Беренче катта 3 мең кеше сыярлык зал урнашкан. Почмакларында манаралар калкып торган вестибюльнең чыгынты күләме төп бинаның төньяк фасадына тоташкан. Икенче катта игътибарны вестибюль өстендәге залга ачылучы балкон җәлеп итә. Өченче катта класслар һәм залның өченче ярус балконы урнашкан. Бинаның төп көнбатыш фасадында эчке өслегә полихром майолик сталактитлар б-н бизәлгән, уксыман ярымгөмбәз б-н төгәлләнгән куышлы, биек порталлы ишек уелган. Көньяк фасадта, төп күләм биеклегендә турыпочмаклы михраб чыгып тора, аның як-якларында бер катлы хуҗалык бүлмәләре урнашкан. Яшерен парапетлар б-н ныгытылган тәбәнәк түбәдән су агу торбаларының санын киметү өчен, катлаулы конструктив чишелеш кулланылган. Намаз залының гөмбәзе тимер-бетоннан. Залны яхшырак яктырту өчен, гөмбәз диварларына һәм барабанына металл рамлы, рәшәткә сыман өлгеле күпсанлы тәрәзә уемнары уелган. Мәчет диварлары — керәч плитәләр б-н; колонналар,



Санкт-Петербургтагы җамигъ мәчет. Архитекторлар Н.В. Васильев, С.С. Кричинский, А.И. фон Гоген. 1910–13.

күтәреп торучы гөмбәз асты а́ркалары яшел мәрмәр б-н тышланган. Мәчетнең композициясендә һәм архитектур-декоратив бизәлешендә традицион принциплар һәм модерн элементлары булган Урта Азия төбәге архит-расының традицион алымнары аралашып килә. 1930 еллар ахырында мәчет ябыла, бина складлар итеп файдаланыла. 1956 да кабат диндарлар җәмгыятенә кайтарып бирелә.

*Әд.:* А м и н о в Д.А. Санкт-Петербургская соборная кафедральная мечеть: Ист. очерк. СПб., 1992; З а г и д у л л и н И.К. Исламские институты в Российской империи: Мусульманская община в Санкт-Петербурге. XVIII — начало XX вв. К., 2003.

*Х.Г.Надыйрова.*

**САНСЕВЬЕ́РА**, ч у р т а н к о й р ы г ы (Sansevieria), агавачалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 60 төре билгеле. Чыгышы — Африка, Көньяк Америка, Азия тропиклары. Яфраклары тамыры янында, итчел яки тиречел, кылычсыман формада, яссы, улаксыман яки цилиндрик, кайбер төрләре чуар — аркылы көмешсыман сызыклы. Чәчәкләре вак, 6 буынлы гади яшькелт-ак чәчәк тирәлекле, яфрак куентыгыннан чыгучы чук чәчәк төркеменә

җыйналган. ТРда кайбер төрләре — зур С. (S. grandis), хана С. (S. hahnii), өч сызыклы С. (S. trifasciata), цилиндрик С. (S. cylindrica) һ.б. — декоратив бүлмә гөле буларак үстерелә. Тамырчасын бүлеп яки яфракларыннан үрчетәләр. Үсемлек һава корылыгына, үтәли җилләргә, сирәк су сибүгә чыдам. Туфракның артык дымлануын һәм темп-раның –5 °С тан түбән төшүен авыр кичерә.

**«САНТЕХПРИБО́Р»**, машиналар төзү һәм металл эшкәртү пр-тиесе, РФдә иң эре сан.-техник арматура җитештерүче (гомуми күләмнең 10% ы, кушу краннарының 30% ы). Казанда урнашкан. Эшләүчеләр саны — 140 кеше (2014); төп продукциясе — төрле модификациядәге су краннары, сөлге киптергечләр (2008). 1941 елда Луганск шәһәреннән (Украина) эвакуацияләнгән һәм 6 нчы тегү ф-касы терр-ясендә урнаштырылган Союзкүләм 543 нче з-д җирлегендә оештырыла, сугыш патроннары эшләп чыгара. 1947 дә Казан союзкүләм механика з-ды итеп үзгәртелә һәм халык куллануы товарлары (тәрәзә һәм ишекләргә куелучы металл кирәк-яраклар, сан.-техник арматура — барлыгы 23 исемдә) җитештерүгә күчерелә. 1957 дән Казан «С.» механика з-ды дип атала, 1991 дән арендадагы пр-тие, 1992 дән АҖ. Пр-тие структурасына төп җитештерү (кою-механика, гальваника, җыю) цехлары һәм ярдәмче цехлар керә. Реконструкцияләр, модернизация, яңа куәтләр (инструментлар цехы һ.б.) сафка басу, җитештерүнең техник җиһазландырылу дәрәҗәсе күтәрелү (цилиндрлы механизм детальләре һәм ачкычлар эшләү өчен чит илләрдән кайтартылган җиһазлар урнаштырылу, «Силлем» автомат линиясе, сан.-техник арматура детальләрен шомарту-ялтырату операцияләрен башкаручы линияләр корылу) нәтиҗәсендә җитештерү күләме күпкә арта. Технологияләрне өзлексез камилләштерү (20 дән артык, ш.и. кокиль формага салып кою, җиз һәм корыч детальләрне өч валентлы хром нигезендә саклагыч-декоратив өслек б-н каплау технологиясе гамәлгә кертелә) продукциянең сыйфатын яхшырту мөмкинлеге бирә. 1970 елларда төрле модификациядәге су краннары җитештерү — 1,2 млн., йозаклар эшләп чыгару 1 млн. данәгә җитә (1960 еллар б-н чагыштырганда, продукция күләме 2 тапкыр арта). 1960–70 елларда Төзелеш материаллары җитештерү сәнәгате министрлыгының Санитария техникасы фәнни-тикшеренү ин-ты (Мәскәү) б-н берлектә пр-тиедә 6 исемдәге 18 төр эшләнмә җитештерү оештырыла. 1947–2013 тә 500 дән артык исемдәге төрле эшләнмә ясау үзләштерелә һәм җитештерелә. 2013 тә төрле модификациядәге 188 мең су краны эшләп чыгарыла.

Чимал б-н тәэмин итүче төп пр-тиеләр — металл буенча: «Ревда төсле металлар эшкәртү заводы» (Свердловск өлкәсе), «Киров төсле металлар эшкәртү заводы» (Киров өлкәсе), «Бологое металлургия комбинаты» (Тверь өлкәсе), «Цветметобработка» (Владимир өлкәсе Кольчугино ш.) АҖләре, «Метснаб» ҖЧҖ (Түбән Новгород ш.), резина-техник эшләнмәләр буенча: «Кварт» АҖ (Казан).

1970–80 елларда пр-тие продукциясе дөньяның 16 иленә чыгарыла, хәзерге вакытта РФ төбәкләренә, Үзбәкстан һәм Казакъстанга җибәрелә. Пр-тие эшләнмәләре СССР ВДНХсының, бөтенсоюз һәм халыкара конкурсларның алтын, көмеш һәм бронза медальләре, 1997–2013 тә Бөтенроссия «Россиянең иң яхшы 100 товары» конкурсы призлары һәм дипломнары, «Россия сыйфаты программасы» конкурсы дипломы б-н билгеләп узыла. Күп кенә эшчеләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 1 кешегә ТРның атказ. машина төзүчесе дигән мактаулы исем бирелә; 3 кеше — Ленин ордены, 4 кеше — Октябрь Революциясе, 16 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 1 кеше — Халыклар дуслыгы, 7 кеше — 3 нче дәрәҗә Хезмәт даны, 25 кеше — «Почёт билгесе» орденнары, 29 кеше медальләр б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре: И.И.Игнатович (1942–50), Г.В.Дмитриев (1950–58), В.П.Головин (1958–61), В.В.Ефимов (1961–70), В.И.Парамонов (1970–82), Г.Т.Сабиров (1982–88), Р.Л.Аргушян (1988–95), Ә.М.Мөхәммәтзакиров (1995–2003), М.В.Латыйпов (2003 тән).

*Әд.:* Михайлов В. Завод һәм аның кешеләре // Татарстан коммунисты. 1960. № 1; Мөхәммәтзакиров Ә. Җитәкче нинди генә булмасын, аның хезмәте ил тудырган шартларга бәйле // Татарстан. 1999. № 9; Могучая сила ответственности. К., 1964; Мухаметзянов Ф. Комплексно решая вопросы качества // Коммунист Татарии. 1985. № 8; Аргушян Р. Акционерное общество «Сантехприбор» // Бизнес. 1993. № 7–8. *М.Ж.Гаитов.*


О.А. Санфирова.

**САНФИ́РОВА** Ольга (Ләйлә) Александровна (2.5.1917, Самара ш. — 13.12.1944; Белоруссия ССРның Гродно шәһәрендә туганнар каберлегендә җирләнә), Сов. Союзы Герое (23.2.1945, үлгәннән соң), гв. капитаны. Милләте буенча татар. Аэроклуб (Мәскәү өлкәсенең Коломна ш., 1937), очучыларның Батайск хәрби авиация мәктәбен (1942) тәмамлый. Ташкент шәһәрендә яши һәм эшли. 1941 елның декабреннән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 46 нчы гв. төнге бомбардировщиклар авиациясе полкының эскадрилья командиры (4 нче һава армиясенең 325 нче бомбардировщиклар авиациясе дивизиясе). 2 нче Белоруссия фронты һава армиясе составында С., дошманның җанлы көчләрен һәм ныгытмаларын юк итү өчен, 630 төнге сугышчан очыш ясый. Сугышчан бурычын үтәп кайтканда һәлак була (парашюты б-н пехотага каршы минага төшә). Ленин ордены, Кызыл Байрак, Александр Невский, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Самарада С.га һәйкәл куела, аның исеме б-н урам атала; Коломнада аэроклубның бер бинасына мемориаль такта (янәшәсенә — бюст) куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000. *М.З.Хәбибуллин.*

**САҢАГАЯКЛЫЛА́Р** (Anostraca), саңагаяклы кысласыманнар асотряды. Якынча 180 төре билгеле. Россиядә — 50. Татарстан терр-ясендә Branchipus stagnalis, Streptocephalus torvicornis очрый, Pristicephalus ыругы вәкилләре дә күренергә мөмкин. Ярым үтә күренмәле матур кыслачыклар, корсак ягын өскә каратып салмак кына хәрәкәтләнәләр. Гәүдәсенең озынлыгы 7 *см* га кадәр, баш, күкрәк һәм корсак өлешләренә бүленә. Күкрәк сегментының һәрберсендә бертөрле яфраксыман парлы аяклар урнашкан. С. — ике җенеслеләр, партеногенез һәм полиплоидия хас. Эмбрион үсеш диапауза һәм катлаулы метаморфоз б-н бара. Гадәттән тыш чыдамлыгы аркасында, С.ның күкәйләре җил б-н таралырга мөмкин, кибү һәм туңуны да кичерә алалар. С. урман-дала һәм дала зоналарындагы вакытлыча булган язгы, сирәк кенә җәйге сулыкларда яшиләр, микроскопик бактерияләр б-н туеналар. Branhipus stagnalis L. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1968. Т. 2; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977. *В.А.Яковлев.*

**САПО́ЖНИКОВ** Леонид Степанович (13.4.1878, Казан губ. Мамадыш ш. — 1937, Казан), вет. хирургы, вет. фән. д-ры (1934), проф. (1911). Казан вет. хирурглары фәнни мәктәбен оештыручы. Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1900), шунда ук эшли (бүленеп): хирургия кафедрасында ассистент, приват-доцент, гомуми (1911–18) һәм махсус (1922–37) хирургия кафедралары мөдире. 1907–11 елларда Германия, Голландия, Бельгия, Швейцария, Австро-Венгриянең иң эре вет. клиникаларында стажировка уза. 1918–22 дә Омск вет. ин-ты ректоры, бер үк вакытта хирургия каф. мөдире. Фәнни тикшеренүләре вет. хирургиясе: асептика, антисептика, авыртуны басу, төрле операцияләр техникасын эшләү, абдоминаль хирургия, патогенетик терапия һәм печү ысулларын эшләү өлкәләренә карый. 3 нче дәрәҗә Изге Станислав ордены б-н бүләкләнә.

Хезм.: Оперативное лечение пупочной грыжи у животных // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1906. Т. 23; К вопросу об удалении инородных тел из пищевода лошади наружной эзофаготомией // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1907. Т. 24; Об операционных столах для лошадей // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1933. Т. 42.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006. *М.Ш.Шәкүров.*

**САПО́ЖНИКОВ СӘҮДӘ́ ЙОРТЫ́**, Казанда архит-ра истәлеге (хәзер Казан баш почтамты бинасы). 1910–11 елларда В.А.Трифонов проекты буенча Ф.П.Гаврилов катнашында модерн элементлары булган неоклассицизм стилендә сәүдәгәр Ф.М.Сапожни-

ковның сәүдә йорты буларак төзелә. Өч катлы кирпеч бина ян-як канатлары булган П-рәвешле симметрик формада: көнбатыш ягы хәзерге Рәхмәтуллин урамына чыга, көнчыгыш канатның төп фасады Кремль урамына карый, вертикаль буенча ул үзәк ризалит б-н бүленгән. Ризалитның аскы өлешендәге төп ишекнең ян-ягы ике дорик колонна б-н ныгытылган. 1920 елларда почтамт өчен бинаның эчке бүлмәләре яңача планлаштырыла. 1930 елларда бинаның икенче катын уң



Сапожниковның сәүдә йорты. Казан. Архитекторлар В.А.Трифонов, Ф.П.Гаврилов. 1911. 1920 еллар фоторәсеме.

якта янәшә торган, почтамт ихтыяҗлары өчен кулланылган ике этажлы йорт б-н тоташтыралар. 1970 елларда корпусның беренче каттагы бүлмәләре Кремль урамы ягыннан реконструкцияләнә; аларда почтамтның үзәк залы һәм башка хезмәтләре урнаша.


*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

**САПО́ЖНИКОВА** Надежда Михайловна (26.3.1877, Казан — 1942, Мәскәү өлкәсенең Звенигород р-ны Николина Гора пос.), нәкышьче, коллекционер, меценант, педагог. Казан сәүдәгәрләре гаиләсеннән. 1910 елда Казан сәнгать мәктәбен тәмамлый, Н.И.*Фешин* укучысы. 1910–12 елларда Парижда, Витти Ирекле сәнгать академиясендә һәм рәссам К.Ван Донген остаханәсендә укый. 1912 дән үзенең Казандагы, соңрак сәнгать тормышының үзәге булып киткән шәхси китапханәсендә эшли: анда рәссамнар Н.И.Фешин, В.Э.*Вильковиская*, А.Г.*Платунова*, К.К.*Чеботарёв*, В.А.Попов һ.б. җыела торган була. 1919–24 тә Казан ун-ты рабфагында рәсем укыта, 1924–25 тә Казан архит-ра-техник ин-тында нәкышь остаханәсе б-н җитәкчелек итә. 1932 дә Мәскәүгә китә, 1936 га кадәр мәктәпләрдә укыта.

С.ның беренче картиналарында Н.И.Фешин мәктәбе йогынтысы: кызчык портреты, автопортрет (1910 еллар), М.Э.Ольцина (1911), В.В.Адоратский (1913) портретлары; соңрак К.Ван Донген нәкышь алымнары сизелә: К.К.Чеботарёв, А.А.Боратынский, С.Э.Вильковиский портретлары, автопортрет (барысы да 1914–16) һ.б. С.ның, башлыча, Казандагы дуслары һәм туганнары төшерелгән портретларына башкару алымнарының җиңеллеге, табигыйлеге, образларның кабатланмас үзенчәлеге хас: «Толымнары сүтелгән гүзәл» (1910), «Казан бикәсе портреты» (1914–15), В.В.Адоратский, Поля Попова портретлары (икесе дә — 1927–29).

С., нәкышь картиналары туплаучы буларак (җирле рәссамнар И.А.Никитин, К.К.Чеботарёв, А.Г.Платунова, В.А.Попов һ.б.ның картиналарына заказлар бирә һәм сатып ала), Казанның мәдәни тормышында тирән эз калдыра, Россиядә Н.И.Фешин картиналарының иң бай тупланмаларының берсенә ия була. Казан сәнгать мәктәбендәге матди ярдәмгә мохтаҗ укучыларның уку хакын түли, нәкышь һәм гамәли-бизәлеш сәнгатен өйрәнү өчен, үз остаханәсен биреп тора, анда ш.у. татар кызлары да белем ала (С. остаханәсендә башкарылган чигү үрнәкләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана). Окт. рев-циясеннән соң остаханә бинасында түләүсез студия оештыра, әмма тиздән остаханәсеннән мәхрүм ителә. 1920 дә студия халык мәгарифенең шәһәр бүлегенә бирелә (С. студия мөдире итеп билгеләнә). С.ның вафатыннан соң тупланма бертуганының кызы В.В.Адоратскаяга, 1963 тән С.Н.Разумов карамагына күчә. С. тупланмасындагы әсәрләрне ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее сатып ала. Казан вакытлы күргәзмәләрендә (1909, 1914–1916), Казандагы 1 нче һәм 2 нче дәүләт сәнгать һәм фән күргәзмәләрендә (1920, 1921), 45 нче Күчмә сәнгать күргәзмәләре ширкәте картиналары күргәзмәсендә (Петроград, 1917) катнаша.

С. әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Казанда Е.А.Боратынский музеенда, Мәскәүдә И.И.Галиевнең шәхси тупланмасында һ.б.да саклана.





Н.М.Сапожникова. 1. «Кыз бала портреты». 1910 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. «К.К.Чеботарёв портреты». 1914–16. И.И.Галиев тупланмасы (Мәскәү).

С.ның Н.И.Фешин иҗат иткән портретлары ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Сан-Диего шәһәрендәге Сынлы сәнгать музеенда (АКШ) саклана.

*Әд.:* Тулузакова Г.П. Надежда Михайловна Сапожникова // Коллекционеры, меценанты, благотворители (Россия XVIII — XX вв.). СПб., 1996; Ключевская Е.П. Надежда Сапожникова: личность и образ // Татарстан. 1997. № 3.

*Г.П.Тулузакова.*

**САПОНА́РИЯ**, к. *Сабын үләне*.

**САПРОПЕ́ЛЬ** (грек. saprós — черек, pēlós — ләм), органик-минераль ләмле төче сулык (күбесенчә урман зонасындагы) утырмалары. С.нең органик матдәләре аминок-та, гумин һ.б. к-талардан тора, алар исә суда яшәүче организмнарның таркалу продуктлары, үсемлек калдыклары хисабына барлыкка киләләр; минераль өлеше — балчыксыл һәм комсу материалдан, макро- (кальций, магний һәм фосфатлар) һәм микроэлементлардан (марганец, бакыр, тимер һ.б.) тора. Яңа вакытта тотып карауга майлы, яшькелт көрән төстә, кипкәннән соң каты. Татарстан терр-ясендә С. турында беренче мәгълүматлар 19 йөз ахырына карый, бу вакытта җирле курортларда шифалы ләмнәр тикшерелә башлый. С.не систематик рәвештә өйрәнүләр 1930 еллардан торфны геол.-разведкалау эшләре б-н бергә башлана. 21 йөз башына С. ресурслары 16 млн. *т* дан арта, 50 дән артык чыганак тикшерелә. Сәнәгый запаслар (3 чыганак буенча) — 3,2 млн. *т* дан артык, аеруча зур ятмалар — Чаллы шәһәре р-нында (Аккүл). С. органик ашлама, әче туфракларны известьләүдә химик мелиорант буларак, компост әзерләү, терлек һәм кош азыгы әзерләү өчен өстәмә минераль азык, ләм б-н дәвалау һ.б.да кулланыла.

*Әд.:* Агроминеральные ресурсы Татарстана и перспективы их использования. К., 2002.

*Н.И.Афанасьева.*

**САПРЫ́ГИН** Николай Евменьевич (23.10.1877, Орёл губ. Брянск ш. — 1942, Архангельск ш.), революцион хәрәкәттә катнашучы. Дворяннар нәселеннән. Казандагы Икенче ир балалар гимназиясен тәмамлый (1898). 1898–1903, 1907 елларда Казан ун-ты студенты. Сәяси чыгышларда катнашканы өчен, университеттан куыла. 1902 дән Казандагы «Кызыл Хач» җәмгыяте әгъзасы. 1903 тә РСДРПның Казан ком-ты җитәкчеләреннән берсе. 1903 нең июнендә кулга алына һәм Вологда губернасына сөргенгә җибәрелә, анда ул революцион эшчәнлеген дәвам итә. 1907–12 дә Казан дары з-дында мастер; Казанда с.-д. түгәрәкләре оештыручы. 1912 дән Архангельск губернасында сөргендә була. Окт. рев-циясеннән соң Архангельскида партия һәм дәүләт эшендә. 1924–29 да — Архангельск Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советының губерна башкарма ком-ты каршындагы, 1929–31 дә Төньяк эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советының край башкарма ком-ты каршындагы төньяк төбәкләрдә яшәүче азсанлы халыкларга ярдәм итү ком-ты рәисе. 1931–38 дә Бөтенроссия ҮБК Президиумы каршындагы Төньякта яшәүче азсанлы халыкларга булышлык итү ком-тында (Ир-

кутск ш.). 1939 дан Архангельск өлкә архивында.

*Әд.:* С т р а х о в а В.Е. Николай Сапрыгин. Архангельск, 1964; Н а ф и г о в Р.И. Сапрыгин Николай Евменьевич // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2; Д о л г о в Е.Б. Формирование первых комитетов РСДРП в г.Казани в 1903 году // Актуальные проблемы развития социалистического общества. К., 1991; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

*Е.Б.Долгов.*

**САПСА́Н,** ч ы н л а ч ы н (Falco peregrinus), лачын кошлар семьялыгындагы кош. Антарктида һәм Көньяк Американың шактый өлешеннән кала, бөтен Җир шарында таралган. Татарстан терр-ясендә 3–5 пар оялый. Миграция чорында 20–30 кош була. Гәүдәсенең озынлыгы 40–50 *см*, канат җәеме 85–120 *см*. Авырлыгы 600–1300 *г* (ана кошлар аталарына караганда зуррак). Каурый капламы тыгыз, каты. Өске ягы күгелҗем-кара, асты аксыл-чуар төстә, башының ян-ягында кара



«мыеклар» аерылып тора. Гәүдәсе зур, түше киң, канатлары киң, очлы, койрыгы чагыштырмача кыска, бармаклары очлы, нык бөгелгән озын тырнаклы. Ояларын биек агачларда, текә ярларда, каралтыларда кора. С. гомерлеккә парлаша. Кызгылт-көрән 2–4 йомырка сала. Нигездә, кошлар (күгәрчен, үрдәк, шөлди, ала каргалар) б-н туклана. Түбәннән очканда тизлеге 300 *км/сәг* кә (кошлар арасында иң зур тизлек) җитә. Күп кенә халыклар эпосында С. — матурлык һәм батырлык гәүдәләнеше; геральдикада аеруча еш кулланылучы үрнәк. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**САПУ́ГОЛИ** (Сабакүл) авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 33 *км* көньяктарак, Казан–Атабай автомобиль юлы буенда. 2010 елда 24 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1557 еллар тирәсендә Казан ханлыгы чоры авылы урынында нигезләнә. Авылның хуҗасы төрле елларда төрле алпавыт була (1565 тә — С.М.Кайсаров). Халкы 1599 да — Сарай, 1797 дә Удел ведомствосына карый; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тимерчелек, арба ясау, он тарту, ит сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.да Казан Богородица чиркәве, земство мәктәбе (1886 да ачыла), 4 җил тегермәне, тимерчелек остаханәсе, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1525,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Столбище волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1646 да — 184, 1782 дә — 157 ир-ат; 1859 да — 748, 1897 дә — 1121, 1908 дә — 1121, 1920 дә — 1063, 1926 да — 1019, 1949 да — 592, 1958 дә — 448, 1970 тә — 323, 1979 да — 189, 1989 да — 52, 2002 дә — 51 кеше.

*Әд.:* История Лаишевского края. Чебоксары. 1997.

**САРАБИККО́Л** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 55 *км* көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 689 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1746 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә; игенчелек, терлекчелек, тегүчелек, җилгәргеч һәм орчык ясау, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 1883 елгы мәгълүматларга караганда, С.да мәчет, су тегермәне, нефть з-ды була. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәктәп, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2681 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва Кармалкасы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1969 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1746 да — 56, 1785 тә — 114 ир-ат; 1795 тә — 178, 1859 да — 1156, 1864 тә — 1156, 1889 да — 2008, 1897 дә — 2004, 1900 дә — 2551, 1910 һәм 1920 дә — 2580 шәр, 1926 да — 2207, 1938 дә — 1560, 1949 да — 1358, 1958 дә — 1975, 1970 тә — 1317, 1979 да — 1035, 1989 да — 769, 2002 дә — 735 кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**САРАВЫ́Л** елгасы, Идел алдында, Коры Үләмә елгасының (Зөя елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 14 *км*, бассейнының мәйданы 58 *км*$^2$. Идел буе калкулыгы буйлап Кама Тамагы р-нында ага. Елга башы Балчыклы авылыннан 8 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Олы Бортас авылыннан 1 *км* көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 77 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. С.ның 1,1 дән 2,9 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,43 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 132 *мм*, ташу агымы катламы 120 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче унконлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,025 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**САРА́Й-ГӨЛЕСТАНИ́** Мәхмүд (тулы исеме Мәхмүд бине Габдулла әс-Сараи әл-Каһирәви) (? — 1398, Каһирә, Мисыр), шагыйрь, дәүләт эшлеклесе. Яшьлек елларында Алтын Урданың Гөлестан, Сарай әл-Җәдид шәһәрләрендә яши, 1370–80 елларда Мәмлүкләр Мисырына күчеп, Бәркук солтан (1382–99) сараенда «инша диваны» — канцелярия башлыгы (вәзир) булып тора. Язма чыганакларда төрле жанрларда язылган күпсанлы әсәрләр авторы буларак искә алына. Безнең көннәргә кулъязма «*Китабе Гөлестан бит-төрки*» җыентыгында робагый жанрындагы бер шигыре сакланып калган.

*Әд.:* М и ң н е г у л о в Х. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976; ш у л у к. Татарская литература и Восточная классика. К., 1993.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**«САРА́Й»,** иҗтимагый-сәяси газета. Бөтенроссия мөселманнары Милли Шурасының Әстерхан бүлеге органы. 1917 елның декабреннән 1918 нең 12 маена кадәр Әстерхан шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Төрле елларда мөхәррирләре — М.Аллабирдиев, Н.Мәүлабирдиев, нашире — Ф.Шаммаси. Башта атнага — 3, аннан 2 тапкыр чыга. Газетада татар халкының бәйсезлек, милли мәдәният, мәгариф, тел үсеше идеясе пропагандалана. Төп игътибар *Милли Мәҗлес* һәм Милли мохтарият эшчәнлегенә, Россиядәге революцион вакыйгалар һәм аларга мөселманнарның, ш.и. татарларның мөнәсәбәтен яктыртуга бирелә. Газета б-н Г.Габәши, Л.Галиәкбәров, Г.Җанибәк, Х.Мулладов хезмәттәшлек итә. Әстерхан мөселман комис-ты тарафыннан Совет хөкүмәтенең большевистик булмаган барлык матбугат органнарының эшен туктату турындагы декреты нигезендә ябыла. Татар-башкорт комис-тын тәнкыйтьләгән мәкалә өчен соңгы саны конфискацияләнә. Газета «Нәшрият» басмаханәсендә басыла, ябылганнан соң, аның җиһазы Әстерхан РКП(б) губерна ком-тының мөселман секциясе карамагына бирелә.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Н у р у л л и н а Р.М. Становление партийно-советской печати на татарском языке (1917–1925). К., 1978.

*З.З.Гыйләҗев.*

**САРА́Й ӘЛ-ҖӘДИ́Д** (гарәп. سراي الجديد — Яңа Сарай) (Сарай Бәркә), урта гасырлар шәһәре, Алтын Урданың башкаласы (14 йөзнең беренче яртысыннан). 1330 елларда, Үзбәк хан заманында, нигез салына. Алтын Урданың эре сәяси, дини һәм мәдәни үзәге. 1340 еллардан анда акча сугыла. Чәчәк ату чоры 14 йөз уртасына туры килә. Шәһәр берничә *км*$^2$ мәйдан биләп тора. Планы — квартал-утар тибында, урамнар үзәктән радиаль рәвештә сузыла. Һәр кварталда җәмәгать биналары, суүткәргеч һәм канализация була; халкы төрле һөнәрчелек (керәч эшләү, тимер эшкәртү һ.б.) б-н шөгыльләнә. Шәһәрнең көньяк-көнчыгыш өлешендә аксөяк утарлары урнаша; якын-тирәсен су б-н тәэмин итү өчен булдырылган ясалма күлләр, мәҗүси һәм мөселман зиратлары чикләп тора. 1395 елда С.әл-Җ. *Аксак Тимер* гаскәре тарафыннан яулана һәм җимертелә. Шәһәр шуннан соң бетүгә йөз тота һәм 1440 елларда яшәү-

дән туктый. Археол. калдыклары (Царёв шәһәрлеге) Актүбә елгасының әүвәлге агымында сулъяк тугайда (Волгоград өлкәсе) сакланган. А.В.Терещенко (1843), Ф.В.*Баллод* (1923), 1959 дан — Г.А.*Фёдоров-Давыдов*, Т.В.Гусева, В.Л.Егоров, Ә.Г.*Мөхәммәдиев*, И.С.Вайнер, Л.Т.Яблонский тарафыннан өйрәнелә.

*Әд.:* Баллод Ф.В. Старый и Новый Сарай — столицы Золотой Орды. К., 1923; Поволжье в средние века. М., 1970; Гусева Т.В. Золотоордынский город Сарай ал-Джадид. Г., 1985; Егоров В.Л. Историческая география Золотой Орды в XIII–XIV вв. М., 1985; Фёдоров-Давыдов Г.А. Золотоордынские города Поволжья. М., 1994. *И.Л.Измайлов.*

**САРА́Й БАТУ́**, к. *Сарай әл-Мәхрусә.*

**САРА́Й БӘРКӘ́**, к. *Сарай әл-Җәдид.*

**САРА́Й әл-МӘХРУСӘ́** (гарәп. سراي المحروسه — Аллаһ саклаган Сарай) (Сарай Бату), урта гасырлар шәһәре (13–15 йөзләр), 1254 ел тирәсендә Батый хан тарафыннан нигез салына. Алтын Урданың беренче башкаласы (14 йөзнең 30 нчы елларына кадәр). Алтын Урданың иң эре шәһәрләреннән берсе, аның икътисади һәм сәүдә үзәге, 1282 елдан акча сугыла. Шәһәрдә 80 меңләп кеше яшәгән. Аксак Тимер Идел буена яу б-н килеп, *Терек елгасы буендагы сугышта* (1395) Алтын Урда гаскәрләрен җиңгәннән соң да җимерелмичә кала, 15 йөз уртасына кадәр үзенең әһәмиятен югалтмый; татар бистәләре 16 йөзгә кадәр саклана. Шәһәр корылмалары 1578 елда русларның Әстерхан кальгасын төзегәндә җимертелә. Бистәләре б-н бергә шәһәр 36 *км*² мәйдан били. Корылмалары тыгыз итеп, кварталлап урнаштырылган, үзәк өлешендә — сууткәргеч һәм канализация челтәре. Һәр кварталда базар, мәчет һ.б. җәмәгать биналары була. Һөнәрчеләр (тимер эшкәртүчеләр, чүлмәкчеләр, зәркәнчеләр, сөяк эшләнмә осталары һ.б.) аерым кварталларда яши. Шәһәр халкының йортлары, башлыча, яндырылмаган кирпечтән салына. Зиннәтле аксөяк йортлары, зиратлар шәһәр читендә урнаша. Әстерхан өлкәсенең Селитренное авылы янында табылган археол. калдыклары 1923 тә Ф.В.Баллод, 1959 дан соң Г.А.*Фёдоров-Давыдов*, Т.В.Гусева, В.Л.Егоров, Ә.Г.*Мөхәммәдиев*, Л.Т.Яблонский, Э.Л.Зивилинская һәм А.Ә.Борһанов тарафыннан өйрәнелә.

*Әд.:* к. *Сарай әл-Җәдид* мәкаләсе. *И.Л.Измайлов.*

**САРА́Й ҺӘМ ДОН БУЕ́ ЕПИ́СКОПЛЫГЫ**, Рус православие чиркәвендә чиркәү адм.-терр. берәмлек. 1261 елда Сарай әл-Мәхрусә шәһәрендә Киев митрополиты Кирилл III тарафыннан Алтын Урдадагы православие динендәге христианнарны «рухи ныгыту өчен» оештырыла. Епископлык башлыгы, гадәттә, ханнар янында торган, гыйбадәт ирегенә ия булган, ясак түләүдән азат ителгән; аның дәрәҗәсе ханның махсус кануны б-н сакланган, аны бозган кешегә үлем җәзасы бирелгән. Епископлар рус кенәзләре һәм ханнар арасында дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыруда арадашчы буларак зур роль башкарганнар: мәс., Переяслав һәм Сарай епископы Феогност (1296–1313) Мәңгү Тимер ханның Византиядәге илчесе була (1266–82). 1454 тә кафедра епископ Вассион тарафыннан Мәскәүгә күчерелә, аның җитәкчеләре Мәскәү митрополитының иң якын адм. ярдәмчеләренә әверелә. Патриархлык оештырылганнан соң (1589), Сарай һәм Дон буе епископларын патриарх вазифаларын вакытлыча башкару хокукы бирүче митрополитлар дәрәҗәсенә күтәрәләр. Епископлык исемнәре дә үзгәрә: Сарай (1261–69), Переяслав һәм Сарай (1269–91), Сарск, Дон буе һәм Козельск (13–14 йөзләр), Крутицы һәм Подрельск (1764 кә кадәр) епископлары. 1764 тә Мәскәү епархиясенә кушылу сәбәпле бетерелә. 1920 дә Крутица һәм Коломна епископлыгы буларак торгызыла.

*Әд.:* Соловьёв Н.А. Сарайская и Крутицкая епархии // Чтения в Имп. Об-ве истории и древностей российских при Моск. ун-те. 1894. Кн. 3; Покровский И.М. Русские епархии в XVI–XIX вв., их открытие, состав и пределы. К., 1897. Т. 1; Полубояринова М.Д. Русские люди в Золотой Орде. М., 1978.

**САРА́Й-ЧОКЫРЧА́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 8 *км* көнчыгыштарак, Кесмәс елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 198 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1602–03 елгы рус чыганакларында Чегорча исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Татар Чокырчасы исеме б-н мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, йон тетү һәм киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1909 да төзелә; архит-ра истәлеге), мәктәп, су тегермәне (Корайван а. б-н бергә), тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1359,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 88 ир-ат; 1859 да — 453, 1897 дә — 635, 1908 дә — 760, 1920 дә — 761, 1926 да — 682, 1938 дә — 495, 1949 да — 383, 1958 дә — 567, 1970 тә — 267, 1979 да — 122, 1989 да — 148, 2002 дә — 199 кеше.

**САРАЙЛЫ́** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 12 *км* көньяктарак, Минзәлә елгасы буенда. 2010 елда 350 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Сарайлы-Бикмәт исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә; игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 146,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1816 да — 115 ир-ат; 1859 да — 385, 1870 тә — 443, 1897 дә — 776, 1920 дә — 982, 1926 да — 1072, 1938 дә — 1028, 1949 да — 750, 1958 дә — 662, 1970 тә — 652, 1979 да — 510, 1989 да — 334, 2002 дә — 370 кеше.

**САРАЙЧЫ́К**, урта гасырларга (13–16 йөзләр) караган Алтын Урда шәһәре, соңрак Нугай Урдасы башкаласы. Урта Азиядән Европага узучы сәүдә юлының әһәмиятле ноктасы. Урта Азия хакиме Аксак Тимер гаскәрләренең 1395 елдагы явы вакытында җимерелми калган азсанлы шәһәрләрнең берсе. Иң югары күтәрелешкә 14 йөздә — 15 йөз башында, нугай бәкләре резиденциясе һәм Идел арьягының мөһим сәяси, хуҗалык-сәүдә һәм дини үзәге булып торган вакытында ирешә. 1580 дә Җаек казаклары тарафыннан җимертелә; акрынлап бетүгә йөз тота. Археол. калдыклары Гурьев өлкәсенең (Казакъстан) Сарайчык авылы янында табыла. С. 200 елдан бирле фәнни яктан өйрәнелә, тикшеренү нәтиҗәләре В.Н.Татищев, П.И.Рычков, П.С.Паллас, А.Левшин, В.Г.Тизенгаузен, А.Н.Кастанье, В.В.Григорьев һ.б.ның хезмәтләрендә тасвирлана. Археол. өйрәнүләр Ф.Гебель (1834), Н.К.Арзютов (1937), А.Х.Маргулан (1950), Г.И.Пацевич (1950 еллар) һәм Л.Л.Галкин (1970–80 еллар) тарафыннан алып барыла. 1996 дан Казакъстан Респ-касы Археол. ин-тының Көнбатыш Казакъстан археол. экспедициясе планлы рәвештә археол. тикшеренүләр б-н шөгыльләнә (җитәкчесе — З.С.Самашев). Күп кенә корылмалар (мәчетләр, торак һәм хуҗалык биналары, төрбәләр) өйрәнелә, урта гасырлардагы шәһәр халкының хуҗалык итү һәм көнкүреше тарихы буенча байтак материал туплана.

*Әд.:* Егоров В.Л. Историческая география Золотой Орды в XIII–XIV вв. М., 1985; Фёдоров-Давыдов Г.А. Золотоордынские города Поволжья. М., 1994; Гончаров Е.Ю. О городище Сарайчик // Диалог культур Евразии: Вопросы средневековой истории и археологии. К., 2001; Тасмагамбетов И., Самашев З. Сарайчик. Алматы, 2001; Пачкалов А.В. Время возникновения города Сарайчук: Нумизматические и археологические материалы, письменные источники // Междунар. (XVI Уральское) археол. совещание: Материалы междунар. науч. конф. Пермь, 2003. *И.Л.Измайлов.*

**САРАКТА́Ш** районы, Оренбург өлкәсенең үзәгендә урнашкан. Хәзерге чикләрендә 1965 елда оештырыла. Мәйданы — 3,6 мең *км*². Үзәге — шәһәр тибындагы Саракташ посёлогы (Оренбург шәһәреннән 105 *км* көнчыгыштарак). Халкы — 40288 кеше (2013). Татарлар саны: 1989 да — 6544, 2002 дә — 7149, 2010 да — 6691 кеше. Татарлар, тупланып, Күлчүм, Чишмә, Жёлтое, Яңавыл, Карагуҗа, Новочеркасск, Рәдүт, Татар Саракташы, Әбләз һәм Ислаевка авылларында яшиләр. С.р. терр-ясендә татарлар 1730–40 елларда Россия империясенең халык сирәк урнашкан көньяк-көнчыгыш чикләрен үзләштерүгә бәйле рәвештә урнаша башлыйлар. Хәзерге вакытта районда этник-мәдәни компонентлы 7 мәктәп, Рәдүт авылы мәдәният йорты каршында татар театры (1973 тән халык театры исемен йөртә) эшли. 2004 тә районда татар өлкә мәдәнияте бәйрәме үткәрелә. 9 мәчет эшли. Татар авылларында мамык шәл-

ләр, өс-баш киемнәре бәйләү киң җәелгән. Районда 18 йөз уртасында Казан губернасыннан монда күченгән нугай нәселләре дә яши. Шагыйрьләр Г.Г.*Рәдуди*, Т.Г.*Ченәкәй*, М.*Җәлилнең* тормышлары һәм хезмәт эшчәнлекләре С. р-ны б-н бәйле.

*Әд.:* Саракташский район Оренбургской области: Краевед. атлас. Оренбург, 2006.

**САРАЛА́Н УРМАНЫ́**, Лаеш р-ны терр-ясендәге урман массивы, Татар Сараланы авылыннан (исеме шуннан) көньяктарак; Идел-Кама табигать биосфера саклаулыгы Саралан участогының нигезен тәшкил итә. Мәйданы 4170 *га*. Идел елгасының дүртенчел чор тугай өсте террасаларында, ш.у. 1 нче тугай өсте террасасының Куйбышев сусаклагычы сулары астында калуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән утрауларда урнашкан. Аның өслеге дюналы рельеф барлыкка китерүче комсу утырмалардан тора. Юкә катнаш кыяклы-үләнле наратлыклар таралган, туфрак өслегендә камышсыман чәчбай һәм урман кыска сабагы өстенлек итә; ара-тирә нарат җиләге, яшел мүкләр, бер яклы рамишия, дарулы сөләйман мөһере очрый. Ике тугай өсте террасаларында, кәсле-көлсу туфраклы вак бөртекле комнарда һәм соры урман туфраклы лёссыман комсыл балчыкта юкәлек һәм имәнлекләр өстенлек итә, урман эчендә каен, усак һәм яшь өрәңге агачлары да күп. Шактый зур мәйданны кисенделәр һәм элекке имәнлекләр урынында үсеп чыккан каен һәм усак урманнары алып тора. Урмансыз көньяк тау битләрендә дала үсемлекләре (каурый кылган, дала чиясе, чәнечкеле слива, күгелҗем нечкә сабак, улаксыман солыча үскән участоклар урнашкан. С.у.ның үсемлек капламы 26 урман тибыннан тора. 170 *га* мәйданда, нигездә, имәннән торучы урман культуралары булдырылган. Үсемлекләрнең — 1300, гөмбәләрнең 720 төре исәпләнә. Умырткасызларның — 3000, умырткалы хайваннарның 250 төре билгеләнгән, ш.и. бурсык, бүре, янутсыман эт, сусар, үр куяны, кабан дуңгызы, кәҗәболан, көртлек, урман күгәрчене, һөд-һөд кошлар, гади кара елан яши.



Саралан урманы. Куйбышев сусаклагычы ягыннан күренеше.



Саралан урманы. Өрәңге-сәрдәле имәнлек.

*Идел-Кама саклаулыгы* оештырылганга (1960) кадәр С.у. Лаеш урман хуҗалыгы карамагында була, аның терр-ясендә берничә тапкыр тоташ кисүләр үткәрелә. Саклаулык режимы кертелү б-н, әкренләп әлеге зонага хас үсемлекләрне торгызу эше бара. 2005 елдан ЮНЕСКОның «Кеше һәм биосфера» («Человек и биосфера») (МАБ) программасы буенча зур Идел-Кама биосфера резерваты саклаулыгы нигезе булган ике участокның («Раифа урманы» б-н бергә) берсе булып С.у. тора.

*Әд.:* Порфирьев В.С. О растительном покрове Волжско-Камского заповедника // Волжско-Камский государственный заповедник. К., 1975; Дедков А.П. Речные террасы и четвертичная история Саралы // Тр. Волжско-Камского гос. природного заповедника. 2002. Вып. 5.

*В.Б.Иванов.*

**САРАНЧАЛЫЛА́Р** (Acridoidea), турыканатлылар отрядыннан кыска мыеклылар асотрядындагы бөҗәкләр өссемьялыгы. Турыканатлылар отрядында иң күп санлы төркем. Дөнья фаунасында 10 мең төрдән артык, БДБ илләрендә 600 гә якын төре билгеле, Татарстанда 32 төре теркәлгән. Үсемлекләрдә (фитофилалар) яки туфрак өслегендә (геофилалар) яшиләр. Зурлыклары 1,5 тән 8 *см* га кадәр. Гәүдә озынлыгының яртысыннан артмаган кыска мыеклы һәм ана затларның күкәй салгычы кыска булуы б-н аерылалар. Тавыш аппараты арткы аякларның ботларында һәм канат өслекләрендә. Ботның эчке өслеге буйлап төерле озын рәт сузылган, канат өслеге җепселләренең берсе башкалардан калынрак. Бөҗәк тиз хәрәкәтләнгәндә боттагы төерләре б-н сеңергә ышкыла һәм тавыш чыгара. Кайбер төрләре (чытырдавык саранчалар төре) очкан вакытта да буй сеңерләр ярдәмендә дә тавыш чыгарырга сәләтле. Ишетү органнары колак пәрдәсе б-н томаланган куышлыктан тора, сулыш юлыннан соң, 1 нче корсак сегментының ян-ягында урнашкан. Төрнең яшәү урынына карап, соры, яшел яки көрән төстә. Күкәйләрен күч ясап (чүлмәк рәвешендә) туфракка сала. Кышлаучы стадия булып күкәй тора. Язын аннан суалчансыман формада личинкалар чыга; җәй уртасына (30–40 көннән соң) җенси яктан өлгерәләр.


С.ның 2 формасын аерып йөртәләр: өер булып һәм ялгыз йөрүчеләр. Барысы да күп ашаучы фитофаглар. Кайберләре а.х. культуралары корткычлары: өер булып йөрүчеләр арасында — күчмә саранча, чүл яки Марокко һәм Италия саранчасы; ялгыз йөрүчеләр арасында Себер, төз, Төрекмән, әвернәле вак саранчалар аеруча куркыныч. Татарстанда куркыныч төрләрдән күчмә саранча берән-сәрән очраштыргалый; ш.у. Азия саранчасы (Locusta migratoria), Себер вак саранчасы (Acropus sibiricus), Италия саранчасы (Caliptamus italicus) күренгәли, алар исә уңышка әллә ни зыян китермиләр.

*Н.В.Шулаев.*


**САРА́ПУЛ** шәһәре, *Удмурт Республикасының* көньяк-көнчыгыш өлешендә, Ижевск шәһәреннән 66 *км* ераклыкта урнашкан. 1596 елдан — Кама буендагы ныгытма, 1780 нән шәһәр буларак билгеле. Халкы — 99869 (2013), татарлар — 8501 кеше. 20 йөз башында мөселман җәмгыяте башлангычында шәһәрдә мөселман китапханәсе, ирләр һәм хатын-кызлар өчен мәктәпләр ачыла. 1919 да С.да — олылар, 1922 дә балалар өчен мөселман мәктәпләре ачыла. 1920–30 елларда милли азчылыкның халык мәгарифе бүлеге каршында татар-башкорт мәктәбе, татар-башкорт балалар йорты, мөселман театры, күчмә драма труппасы оештырыла. 1930 елда ябылган мөселман җәмгыяте 1980 дә эшчәнлеген яңадан башлый. 2 мәчет (1995 һәм 1997 дән) бар. 1991 дән Удмурт Респ-касының Татар иҗтимагый үзәге, 1994 тән Татар мәдәнияте иҗтимагый үзәгенең «Йолдыз» Сарапул бүлекчәсе эшли. Удмурт Реп-касының татар яшьләре берлегендәге респ-ка яшьләр җәмәгать оешмасының «Иман» Сарапул бүлекчәсе гамәлдә. 2003–10 да 2 нче гомуми белем бирү урта мәктәбендә татар телен өйрәнүче сыйныфлар була, 21 нче мәктәптә 1995–2000 елларда татар теле факультатив дәресләрдә укытыла, 2000–10 да кайбер сыйныфларда фән буларак өйрәнелә. Шәһәрнең ике мәктәбендә татар телен һәм татар мәдәниятен өйрәнүче сыйныфлар ачыла. «Халык мәдәнияте йорты» муниципаль мәдәният учреждениесе каршында Татар мәдәнияте үзәге оештырыла. 1993 тән «Яшьлек» татар җыры үзешчән ансамбле эшли. Ел саен «Халкым белән горурланам» исеме астында татар мәдәнияте көннәре, балалар өчен М.Җәлил һәм Г.Тукай истәлегенә багышланган шигырь бәйрәме, *Сабан туе* уздырыла. Үзешчән татар шагыйрьләренең җәмәгать берләшмәсе эшли.

*М.В.Овчинникова, В.В.Кашина.*

**САРА́ПУЛ КАЛКУЛЫГЫ́**, Кама һәм Иж елгалары арасында, Удмурт Респ-касы һәм ТР терр-ясендә (Иж һәм Бимә субүләрендә көньяк-көнбатыш чик); төньякта Үзәк Удмурт түбәнлеге б-н чиктәш. Өстенлек итүче биеклек — 180–200 *м*, макс. — 248 *м*, ТР терр-ясендә — 229 *м*. Өслеге Пермь системасы Казан һәм татар ярусларының известьташ, доломит, балчык, мергель һәм комташларыннан тора; елга үзәннәрендә аллювиаль



Сарапул калкулыгы. Әгерже районы.




утырмалар үсеш алган. Терр-я елга үзәннәре, сыза һәм ерымнар челтәре б-н тармакланган. Татарстан чикләрендә Бимә, Кады, Шихостанка кушылдыклары б-н Кырыкмас һ.б. кече елгалар ага, алар Иж һәм Кама елгаларына коя. Елга үзәннәренең күп өлеше асимметрияле: көньяк һәм көньяк-көнбатыш битләре текәрәк, төньяк һәм төньяк-көнчыгыш битләре авыш. Табигый үсемлекләр сизелерлек дәрәҗәдә кимегән. Караңгы ылыслы һәм катнаш урман участоклары, комсу һәм комсыл балчыклы елга террасаларында нарат урманнары сакланган.

*О.В.Ерёгин.*

**САРА́ПУЛ ӨЯЗЕ́**, 1796–1920 елларда Вятка губернасында. Үзәге — Чулман елгасының уңъяк ярында, Зур Сарапул һәм Юрман елгалары арасында урнашкан Сарапул шәһәре (1596 елда татар шәһәрчеге урынында патша сарае авылы Вознесенское буларак нигезләнә; 1599 га авыл ныгытыла; 1616–1737 дә — Казанның, соңрак Пензаның шәһәряны шәһәрчеге санала; 1738 дән сарай бистәсе, 1780 нән өяз шәһәре). Баштарак Казан өязенең Арча даругасы составына керә; Сарапул округасы дип йөртелә (1596–1708). 1639 да С.ө.нең бер өлеше (округасы б-н Сарапул шәһәре) Пензага теркәлә, 1708 дә Азов губернасына кертелә, әмма Казан воеводасы Н.Кудрявцевның «телдән белдерүе» буенча терр-ясе составына округасы б-н Сарапул да кергән Пенза шәһәре Казан губернасына теркәлә, өязнең бер өлеше (округасы б-н Каракүл авылы) Уфа шәһәренә кертелә. 1719 да С.ө. Пенза һәм Уфа провинцияләре составында Казан губернасына кертелә. 1738–80 елларда С.ө.нең бер өлеше Уфа губернасының Усы провинциясе составына керә; 1781 дән С.ө. терр-ясе — Вятка наместниклыгы, 1796 дан Вятка губернасы составында. С.ө. Вятка губернасының көньяк-көнчыгыш өлешен биләп тора. 19 йөз башына көнбатышта — Малмыж өязе, көньякта, көньяк-көнчыгышта — Вятка губернасының Глазов өязе, төньяк-көнчыгышта — Пермь губернасының Оханск һәм Оса өязләре, көньяк-көнчыгышта — Уфа губернасының Бөре өязе, көньякта һәм көньяк-көнбатышта Вятка губернасының Алабуга өязе б-н чикләшә. Өязнең көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре — Вятка елгасы бассейны елгалары, күпчелек өлеше Камага коючы елгалар: Вотка, Лип, Падка, Зур һәм Кече Кивара, Сидоровка кушылдыклары б-н — Сива; Кече Сарапулка, Светлая, Чёрная һ.б. кушылдыклары б-н — Сарапул; Кырыкмас, Позим, Сылычка, Чур, Люк, Лудзя, Әгерҗе һ.б. кушылдыклары б-н Иж елгасы сулары б-н юыла. Мәйданы 13108,1 кв. чакрым (1897). Халкы 408058 кеше (198572 ир-ат, 209486 хатын-кыз), ш.и. руслар — 71,2%, удмуртлар — 23,9%, татарлар — 1,77%, башкортлар — 1,25%, типтәрләр — 0,87%, марилар — 0,58% (1897). Адм.-терр. яктан өяз станнарга, волостьларга һәм полиция районнарына бүленә. Станнар составы, волостьларны станнарга кертү, өяз терр-ясе үзгәреш кичереп тора. 1658 дә Пермь губернасының Оханск һәм Оса волостьлары С.ө.ндә була. 4 нче ревизия вакытында (1782) С.ө.нең Чыпца елгасының югары агымындагы бер буй төньяк җирләре Глазов өязенә, көньяк-көнбатыштагы кечерәк өлеше Алабуга өязенә карый. Малмыж өязенең төньяк-көнчыгыш өлеше ш.у. С.ө.нә кертелә. 1783 тә Сарапулга Оханск провинциясе җирләре өстәлә. 1797 дә, Вятка наместниклыгы таркалу һәм Малмыж өязе бетерелү нәтиҗәсендә, С.ө.нә Селты һәм Уҗәл волостьлары кушыла. 6 нчы ревизия вакытында (1811) өяз составына Николаевск волосте өстәлә, Селты волосте Глазов өязенә бирелә (1817 дән Селты һәм Уҗәл волостьлары Малмыж өязенә күчерелә). 1870 елга станнар саны өчтән (үзәкләре — Шаркан а., Воткинск Заводы, Каракүл а.) — бишкә, волостьлар саны 39 га җитә; Воткинск Заводына полиция приставы билгеләнә. 1 нче станга (Дебёсы а., 1903–04 тә — Шаркан а.) — Зур Пурга, Дебёсы, Зюзино, Липовка, Петропавловский, Полозово, Тойкино, Тыловай, Чутыр һәм Шаркан волостьлары; 2 нче станга (Июльское а., 1880–1904 тә — Воткинск Заводы) — Гольяны, Завьялово, Июльское, Нечкино, Перевозное, Светлое, Сосновка һәм Якшур-Бодья волостьлары; 3 нче станга (Ижевск Заводы, 1880–1904 тә Сарапул а.) — Ижевск-Нагорный, Ижевск-Заречный, Люк, Иске Венья волостьлары; 4 нче станга (Әгерҗе а.) — Әгерҗе, Зур Нырья, Бураново, Кияс, Козлово, Нылга-Жикья, Пурга, Сарапул һәм Юрино волостьлары; 5 нче станга (Каракүл а.) — Арзамас, Воткинск, Галаново, Исәнбай, Каракүл, Мазунино, Сүҗде (Мостовое) һәм Чыкалда волостьлары керә. 1880–1904 тә 2 полиция районы эшли: Ижевск (аңа 3 нче станнан Ижевск-Нагорный һәм Ижевск-Заречный волостьлары бирелә; 1905 тән әлеге волостьлар 4 нче станга теркәлә) һәм Воткинск (Воткинск волостеннан тора). 1880 гә станнардагы волостьлар саны 36 га калдырыла; бу үзгәреш вакытында Липовка, Полозово һәм Тойкино волостьлары – 1 нче станнан 2 станга, Сосновка һәм Якшур-Бодья волостьлары – 2 нчедән 1 нчегә, Нечкино волосте — 2 нчедән 3 нчегә, Завьялово волосте — 2 нчедән 4 нчегә, Люк һәм Иске Венья волостьлары — 3 нчедән 4 нчегә, Козлово, Сарапул, Юрино волостьлары — 4 нчедән 3 нчегә, Мазунино волосте — 5 нчедән 3 нчегә күчерелә. 1892 дә 2 нче станда Кельчино волосте барлыкка килә; 1893 тә Липовка волосте чыгарыла; 1895 тә станга, Пермь губернасы Оханск өязеннән алынып, Кама волосте өстәлә (1896 да волость составыннан 1903 тә бетерелгән Галево волосте аерыла). 1905 тә 5 стан урынына 7 стан төзелә: 1 нче станга (Дебёсы авылы) — Зур Пурга, Дебёсы, Петропавловский, Тыловай, Тойкино һәм Чутыр волостьлары; 2 нче станга (Шаркан а.) — Зюзино, Сосновка, Шаркан, Полозово һәм Якшур-Бодья волостьлары; 3 нче станга (Воткинск Заводы) — Июльское, Кама, Кельчино, Светлое һәм Перевозное волостьлары; 4 нче станга (Ижевск Заводы) — Зур Нырья, Завьялово, Люк, Ижевск-Нагорный, Ижевск-Заречный, Нылга-Жикья һәм Иске Венья волостьлары; 5 нче станга (Тимеевка а., 1916 дан — Әгерҗе а.) — Әгерҗе, Бураново, Исәнбай, Кияс, Пурга һәм Юрино волостьлары; 6 нчы станга (Сарапул а.) — Гальяны, Козлово, Мазунино; Нечкино һәм Сарапул волостьлары; 7 нче станга (Каракүл а.) — Арзамас, Галаново, Каракүл, Сүҗде (Мостовое) һәм Чыкалда волостьлары керә. Воткинск волосте кергән 1 полиция районы сакланып кала. 1906 да 2 нче станда Түбән Лып волосте барлыкка килә. 1907 дә 4 нче станда Нылга-Жикья волостеннан Кыйлуд волосте аерылып чыга, 3 нче станда Кама волостеннан кабат Галево волосте бүленә, Исәнбай волосте (5 нче стан) 7 нче станга теркәлә.

1915 кә волостьлар саны 43 кә җитә. 20 нче йөз башында өяздә 12 земство участогы була. С.ө. халкы, башлыча, игенчелек (арыш, солы, бодай, арпа, борай, тары игелә), терлекчелек, һөнәрчелек (итек, башмак тегү) б-н шөгыльләнә. Кәсепчелек: балык тоту, умартачылык, киез һәм киез итек басу, йон тетү, савыт-саба, арба, мичкә ясау, агач кыру-эшкәртү, агачтан җиһаз эшләү, чыпта сугу, мунчала төшерү, киндер сугу, известь яндыру, кирпеч сугу, тире һәм күн эшкәртү, заводлар өчен утын һәм күмер әзерләү киң таралыш ала; читкә китеп — олаучылык, урман кисү, судноларда эшләү, соңрак бурлак хезмәте б-н шөгыльләнәләр. Халыкның бер өлеше заводларда эшли. 19 йөз ахырында С.ө.ндә 118 завод (34 — күн эшкәртү һәм күн әйберләр тегү, 24 — май язу, 16 — прәннек пешерү, 14 — кирпеч сугу, 6 — аркан ишү, 5 — шәраб, 2 – чуен кою, 2 — җилем кайнату, 2 — терлек мае эретү, 2 – аракы куу һ.б. заводлар), ш.и. Воткинск (Кама-Воткинск) тимер кою з-ды (1759 да граф Шувалов тарафыннан нигезләнә, 1763 тә — Берг-коллегия, 1783 тә — Казна палатасы, 1798 дә Тау эшләре башлыгы идарәсе карамагына тапшырыла), Ижевск корал з-ды (1760 та граф Шуваловның хосусый милке буларак нигезләнә, 1763 тә казнага сатып алына; баштагы чорда — тимер, 1807 дән корал эшләп чыгара) исәпләнә. Өяз Идел буе һәм гомумроссия сәүдәсендә катнаша. 19 йөздә анда 14 ярминкә, 266 сәүдә урыны, 850 базар эшли. Өяз читкә икмәк, урман эшләнмәләре (Самара, Саратов, Әстерхан, Рыбинск, Архангельск шәһәрләренә); житен, киндер, терлек мае (Казанга), күн, күн итек (Түбән Новгород, Эрбет һәм Минзәлә ярминкәләренә) һ.б.ны чыгара. Читтән чәй, балык, тоз, шикәр, тәмәке, бакалея һәм галантерея товарлары кертелә. 19 йөз ахырында өяздә рус милләтеннән булган ир балалар өчен 1 өяз рухани уч-щесе, 1 өяз һәм 1 приход уч-щесе, хосусый пансион һәм 52 башлангыч халык уч-щесе; кыз балалар өчен 1 өяз һәм 1 приход уч-щесе, 12 халык уч-щесе эшли. Татар авылларындагы мәчетләр каршында — мәктәпләр, хәлле халкы күп булган зур авылларда мәдрәсәләр була. Җәдитчә белем бирүче *Буби мәдрәсәсе* аерым танылу ала. 1920 дә Әгерҗе һәм Исәнбай волостьлары — ТАССРга, Ижевск-Нагорный һәм Ижевск-Заречный волостьлары — Вотяк автономияле өлкәсенә (1932 дән — Удмуртия автономияле өлкәсе; 1934 тән — Удмурт АССР), Сарапул өязенең бер өлеше (Кама буе чиге) Пермь губернасына кертелә. 1923–37 елларда Сарапул округы — Урал өлкәсе, 1934–37 дә Киров крае составында була, 1938–39 да Удмурт АССРга кушыла.

Чыг.: Памятная книжка Вятской губернии на 1866 и 1867 годы. Вятка, 1865; Столетие Вятской губернии: В 2 т. Вятка, 1880–81; Кустарная промышленность Вятской губернии: Стат. очерк. Вятка, 1882; Вятская губерния // Первая всеобщая перепись населения Российской империи 1897 г. СПб., 1904. Т. 10; Памятная книжка Вятской губернии и календарь на 1916 год. Вятка, 1915.

*Әд.:* Эммаусский А.В. Исторический очерк Вятского края XVII–XVIII веков. Киров, 1956.

*Д.Г.Мостафина.*

**САРА́ПУЛ РАЙОНЫ́**, *Удмурт Республикасының* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1926 елның 4 ноябрендә оештырыла. Мәйданы — 1970 *км*². Үзәге — Сигаево авылы (Ижевскидан 66 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 24506 (2013), татарлар — 1285 кеше (2010). Татарлар, күбесенчә, Девятово һәм Сигаево авылларында Уральский посёлогында яшиләр. Районда 2: «Чишмә» (Уральский пос. 2002 дән) һәм «Дуслык» (Дулесово а., 2007 дән) татар мәдәният үзәкләре бар. Дулесово авылы мәдәният йорты каршында «Сандугач» татар ансамбле эшли. Районда ел саен *Сабан туе* бәйрәм ителә, 2003 тә «Чишмә» үзәге инициативасы б-н Татар мәдәнияте көне үткәрелә. Уральский посёлогында мәчет төзү планлаштырыла.

**САРА́ТОВ** (Сары Тау) шәһәре, РФдә, *Саратов өлкәсе* үзәге, Мәскәүдән 858 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Идел елгасының уңъяк ярында урнашкан. Беренче фараз — татар торулыгы урынында 1584–89 елларда барлыкка килә, икенче фараз — 1590 да Идел буендагы сәүдә юлларын саклау крепосте буларак нигез салына. Халкы — 840785, татарлар — 14778 (2010). С. терр-ясенә татарлар элек-электән килеп урнаша. 10–13 йөзләрдә *Алтын Урда* составына кергән бу җирләр кыпчак кабиләләренең күчеп йөрү урыны була. Хәзерге С.ның көньягында Алтын Урданың Үкәк шәһәре калдыклары сакланган. 17 йөзнең 2 нче яртысында С.та йомышлы татарлар һәм сәүдәгәрләрдән торган татар җәмгыяте оеша башлый. 1835–39 да шәһәрдә таш мәчет төзелә. 1913–17 дә *Саратов мөселманнары җәмгыяте* хәйрия оешмасы, 1918 дә Мөселман социалистлар ком-ты — татар-башкортларның революцион-демократик оешмасы эшли. Татар телендә «Мөхтәрият» (1917), «Ялкын» (1918–32) г-талары нәшер ителә. 1920–30 елларда С.та — татар мәктәпләре, клуб, 1958–65 тә «Сандугач» җыр һәм бию ансамбле эшли. Хәзерге вакытта шәһәрдә Төбәк татар милли-мәдәни автономиясе (1997 дән), «Сарытау» яшьләр иҗтимагый оешмасы (2003 тән), «Идел» татар мәдәни-агарту берләшмәсе (1989 дан) эшли. Татар гимназиясе һәм балалар бакчасы бар (1992 дән). «Россия мөселманнары» дини берләшмәсе, «Россия мөселманнары берлеге», «Динне яңадан торгызу һәм социаль яклау ислам хәйрия фонды» эшли. 1998 дән «Мусульманский вестник» һәм «Сарытау» г-талары нәшер ителә, айга 2 тапкыр «Саратов» дәүләт телерадиокомпаниясенең «Аллаһу әкбәр» тапшыруы чыга. Мөселман балаларының җәйге лагерьлары эшли. Ел саен татар мәдәнияте көннәре: концертлар, иҗат кичәләре, фәнни-гамәли конференцияләр, ТР кунаклары һәм хөкүмәт вәкилләре б-н очрашулар үткәрелә. «Татарстан» сәүдә йорты җирлегендә ТР һәм РФнең башка төбәкләре эшлекләре б-н презентацияләр оештырыла. Соколовая Гора калкулыгындагы этнография музееның «Саратов өлкәсе халыкларының милли авылы»нда татар җәмгыяте иганәсенә милли көнкүреш элементлары б-н Татар йорты төзелә. *Сабан туе*, *Каз өмәсе* үткәрү гадәткә кергән. 2003 тә ТР ФАнең Ш.Мәрҗани исем. Тарих ин-ты каршында Татар халкын өйрәнү гыйлеме фәнни советының Саратов бүлекчәсе оештырыла. Сов. Союзы Герое Е.Г.*Рамаев*, РФ теннис федерациясе рәисе Ш.Ә.*Тарпищев*, комп. Г.М.*Бикташев*, тарих фән. д-ры Ф.Г.*Рәшитов*, мед. фән. д-ры Я.Ш.*Востриков*, психол. фән. д-рлары Р.Х.Тугушев һәм Р.М.*Шамионов*, а.х. фән. д-рлары Ф.Х.*Бәхтиев* һәм Б.И.*Туктаров*, химия фән. д-ры И.С.*Мостафин*, юридик фән. д-ры Б.Т.*Разгильдиевнең* тормышлары һәм хезмәт эшчәнлекләре С. шәһәре б-н бәйле.

*Әд.:* Энциклопедия Саратовского края (в очерках, событиях, фактах, именах). Саратов, 2002; Золотоордынскому городу Укеку семь с половиной столетий. Саратов, 2002; Рашитов Ф.А. О прошлом и настоящем татарского народа. Саратов, 2003.

**САРА́ТОВ МӨСЕЛМАННА́Р АРАСЫНДА́ МӘГЪРИФӘ́Т ТАРАТУ́ ОЕШМАСЫ́**, мәдәни-агарту оешмасы. 1916 елның маенда Саратов шәһәрендә төзелә. Гамәлгә куючылары — С.А.Казимов (рәис), И.Б.Колахмәтов (сәркәтип), И.М.Курамшин, М.И.Солтанов. Төп максаты — мәктәп һәм мәктәптән тыш белем бирү челтәрен киңәйтү һәм яхшырту, мәгърифәт тарату юлы б-н җәмгыятьчелекнең мәдәни, аң-белем дәрәҗәсен күтәрү. 1916 ның ахырында Саратовның Татар урамындагы махсус бинада уку заллы китапханә ача. 1917 дән соң эшчәнлеге туктала.

*Җ.С.Миңнуллин.*

**САРА́ТОВ МӨСЕЛМАННАРЫ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, хәйрия оешмасы. 1913 елның мартында Саратов шәһәрендә оештырыла. Гамәлгә куючылары — З.М.Енгалычев (рәисе), Х.Измайлов, Б.С.Юскәев, А.Б.Вәлишин, И.Ш.Абушаев, Х.Ю.Акчурин, Б.А.Колахмәтов, У.С.Аитов, С.Курамшин, А.Аитов. Төп максаты — мөселман мәдәни-агарту учреждениеләре үсешенә булышлык итү, мохтаҗ мөселманнарга һәм Беренче бөтендөнья сугышы чорында яралы сугышчыларга, аларның гаиләләренә матди ярдәм күрсәтү. 1917 дән соң эшчәнлеге туктала.

*Җ.С.Миңнуллин.*

**САРА́ТОВ ӨЛКӘСЕ́**, Россиянең Европа өлешенең көньяк-көнчыгышында урнашкан. 1934 елның 10 гыйнварында оештырыла. Мәйданы — 100,2 мең *км*². Үзәге — *Саратов* шәһәре. Халкы — 2496,5 мең кеше, татарлар — 52,8 мең кеше (2010) (1959 да — 34,1, 1970 тә — 43, 1979 да — 47,9, 1989 да — 52,9, 2002 дә — 57,6 мең кеше). С.ө. — төрки халыклар яшәүче төбәкләрнең иң борынгыларыннан берсе. Аның терр-ясе *Төрки каганлык*, *Алтын Урда*, *Нугай Урдасы* составына керә. Алтын Урда чорында берничә дистә авыл, ш.у. дәүләтнең иң төзек һәм матур шәһәрләреннән берсе — *Үкәк* шәһәре була. 17 йөзнең 1 нче чирегендә хәзерге С.ө.нең төньяк өлешен мордва, рус, татар, чуаш крәстияннәре һәм йомышлы кешеләр үзләштерә башлый. Темников, Сембер һ.б. өязләрдән килгән йомышлы һәм ясаклы татарларның күбесе монда 1680 елларда Сызрань-Пенза чик буе киртәләре төзелеше б-н бәйле рәвештә килеп урнаша. 1917 гә кадәр татар халкы күбесенчә авыл җирлегендә яши. 1911 дә

Саратов губернасының Вольск, Кузнецк, Петровск һәм Хвалынск өязләрендә 116 мәчет, 64 мәдрәсә һәм мәктәп эшли. Хвалынск шәһәрендә 2 рус-татар мәктәбе (1907 һәм 1912 дә ачыла) эшли. 1920 дә Покровск (хәзер Энгельс) шәһәрендә Аерым ирекле татар батальоны оештырыла. 1927 дә хәзерге С.ө. терр-ясендә күпчелеген татарлар тәшкил иткән 10 милли волость һәм 227 милли авыл советы исәпләнә. Хәзерге вакытта татарлар, тупланып, Саратов (15,3 мең), Энгельс (6,5 мең), Балаково (4 мең), Пугачёв (3 мең кеше) шәһәрләрендә һәм ш.у. Базар-Карабулак, Балаково, Дергачи, Ершов, Петровск, Саратов р-ннарында яшиләр. Татар иҗтимагый һәм мәдәни оешмалары, нигездә, Саратовта туплана. Өлкә үзәгеннән тыш, «Идел» татар милли-мәдәни үзәге (Балаково; вокаль һәм хореографик төркемнәрне, студияләрне, яшьләр һәм хатын-кызлар клубларын берләштерә), Балаково р-нының һәм Балаковоның мөселман дини берләшмәсе була. С.ө. терр-ясендә татарлар җитәкләгән «Нарат», «ГЭКСар», «Кудашевское» һ.б. эре АҖләре эшли. Ел саен «Идел йолдызлары» өлкә балалар фестивале, мәктәп укытучылары арасында төбәкара «Идел буе халыклары» фәнни-танып белү конференциясе, татар теле һәм әдәбияты буенча өлкә олимпиадасы, Татар мәдәнияте көннәре үткәрелә; Усть-Курдюм авылында *Сабан туе* уздырыла. С.ө.ндә 20 мәчет бар. 1997 дән ТР б-н С.ө. арасында «Дуслык һәм хезмәттәшлек турында килешү» гамәлдә, 1998 дән Казан б-н Саратов арасында дуслык мөнәсәбәтләрен үстерү программасы эшли. 2002 дә С.ө.ндә ТРның Сәүдә-икътисад вәкиллеге (рәисе К.А.Әбләзов) ачыла. Сов. Союзы Герое И.М.*Кудашев*, дәүләт эшлеклесе Б.Х.*Мансуров*, журналист В.Г.*Бәхтияров*, педагог һәм журналист Ш.Х.*Сүнчәләй*, сәяси эшлекле С.*Енгалычев*, шагыйрьләр М.-Й.*Дибердиев* һәм С.Х.*Сүнчәләй*, флейтачы М.И.*Солтановның* тормышлары һәм хезмәт эшчәнлекләре С.ө. б-н бәйле.

*Әд.:* Очерки истории Саратовского Поволжья: В 3 т. Саратов, 2002–08; Рашитов Ф.А. О прошлом и настоящем татарского народа. Саратов, 2003; Энциклопедия Саратовского края (в очерках, событиях, фактах, именах). Саратов, 2002.

**САРА́ТОВ РАЙОНЫ́**, РФдә. *Саратов өлкәсенең* үзәгендә урнашкан. 1937 елда оештырыла. Мәйданы — 1,9 мең *км*². Үзәге — *Саратов* шәһәре. Халкы — 49683 (2013), татарлар — 995 кеше (2010). Татарлар, башлыча, Усть-Курдюм (92 кеше), Сосновка (70), Рыбушка (64), Тархан (78) авылларында, Красный Октябрь (41), Соколовый (37), Красный Текстильщик (30) шәһәр тибындагы посёлокларында яшиләр. Усть-Курдюм авылында «Идел» мәдәни-агарту татар иҗтимагый һәм «Мәхәллә» мөселман иҗтимагый оешмалары, мәчет эшли; ел саен *Сабан туе* үткәрелә. Тархан посёлогы мәдәният сарае каршында «Яшьлек» татар милли ансамбле эшли.



Сарман авылы. 1. Ленин урамы. 2. Район хакимияте бинасы.

**САРБА́Ш** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 37 *км* төньяктарак, Юкәче елгасы буенда. 2010 елда 54 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Турки исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 341,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Лыябаш-Келәүш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 20 ир-ат; 1859 да — 150, 1897 дә — 300, 1908 дә — 338, 1920 дә — 333, 1926 да — 314, 1949 да — 210, 1958 дә — 128, 1970 тә — 189, 1979 да — 165, 1989 да — 98, 2002 дә — 86 кеше.

**САРКЕ́Л** (Шаркил), урта гасырларда (9–10 йөзләр) Дон елгасы буенда Хәзәр каганаты шәһәр кальгасы. 830 елларда византияләр ярдәме б-н төзелә. Хәзәрләр үтенече буенча византиялеләр, кальга төзү өчен, спафарокандидат Петрона Каматирны юллыйлар. Кальганың озынлыгы 193,5 *м*, киңлеге 133,5 *м*. Шәһәрдән канау б-н аерыла, диварларының калынлыгы 3,75 *м*, манаралары, ике капкасы була. Вакытлар узу б-н, эре сәүдә-һөнәр үзәгенә әверелә. 965 тә бөек Киев кенәзе Святослав I тарафыннан басып алына. 12 йөз уртасына кадәр рус кальгасы Белая Вежа була. Акрынлап таркала.

*Әд.:* Артамонов М.И. История хазар. Л. 1962; Плетнёва С.А. Очерки хазарской археологии. М., 2000.

*И.Л.Измайлов.*



Сарман авылының гомуми күренеше.

**САРЛЫ́** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 33 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 470 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1764 тән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.да волость идарәсе урнаша; 2 мәчет, 2 мәктәп, тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 6163 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Эстәрлетамак волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1822 дә — 169 ир-ат; 1834 тә — 337, 1859 да — 863, 1889 да — 1202, 1897 дә — 1466, 1910 да — 1754, 1920 дә — 1295, 1926 да — 917, 1938 дә — 1074, 1949 да — 751, 1958 дә — 732, 1970 тә — 808, 1979 да — 776, 1989 да — 534, 2002 дә — 499 кеше.

**САРМА́Н** авылы, Сарман р-ны үзәге. ТРның көнчыгышында, Ульянов–Уфа тимер юлындагы Бөгелмә станциясеннән 110 *км* төньяктарак, Минзәлә елгасы буенда, Казаннан 296 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 7153 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Сөт, спирт-аракы з-ды. Урта, спорт, сәнгать һәм музыка мәктәпләре, гимназия, район мәдәният йорты. Район тарихы музее. 2 мәчет. 1731 гә кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлек асрау, умартачылык, он тарту, сәүдә б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, С.да мәчет,

мәктәп, 2 су тегермәне була. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; 2 мәчет, мәдрәсә, 2 су тегермәне, тимерче остаханәсе, ашлык саклау-сату һәм 7 бакалея кибете, 1 сыраханә, базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5757 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әлмәт-Муллино волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман р-ны үзәге. Халык саны: 1795 тә — 207 кеше, 1816 да — 170, 1834 тә — 259 ир-ат; 1859 да — 923, 1870 тә — 1062, 1897 дә — 1521, 1906 да — 1505, 1920 дә — 2056, 1926 да — 1727, 1938 дә — 2671, 1949 да — 1720, 1958 дә — 2096, 1970 тә — 2587, 1979 да — 5096, 1989 да — 5388, 2002 дә — 6327 кеше.

**САРМА́Н РАЙОНЫ́**, ТРның көнчыгыш өлешендә урнашкан. Мәйданы — 1385,6 *км*$^2$. 1 шәһәр (Җәлил штп) һәм 22 авыл җирлеген, 68 торак пунктны берләштерә. Үзәге — Сарман авылы. 2015 елда 36,5 кеше (2010 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 90,7%, руслар — 7,6%) яши. Шәһәр халкы — 14,9, авыл халкы — 21,6 мең кеше. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*$^2$ га 26,5 кеше. 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязенә керә,



САРМАН РАЙОНЫ
1:1 000 000
1. Минзәлә районы

1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. Оешкан вакытында С.р.на 57 авыл советы, 119 торак пункт керә, аларда 54282 (татарлар — 48669, руслар — 5613) кеше яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1935 нең 10 февралендә С.р.ның бер өлеше яңадан оешкан Зәй һәм Яңа Юл р-ннарына бирелә (1959 ның 12 октябрендә кире кайтарыла). 1940 та районның мәйданы — 1095 *км*$^2$, халык саны — 36,1 мең кеше, 25 авыл советы, 75 торак пункт була. 1960 та С.р. 1706 *км*$^2$ җир били, аңа 19 авыл советы, 114 торак пункт керә. 1963 нең 1 февралендә ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, С.р.на Зәй һәм Мөслим р-ннарының бер өлеше кушыла. Районның мәйданы — 3230 *км*$^2$, халык саны — 74,5 мең кеше, 37 авыл советы, 198 торак пункт исәпләнә. 1965 нең 12 гыйнварында ТАССРда адм. бүленеш үзгәрү сәбәпле, район терр-ясе — 1797 *км*$^2$, халык саны — 42,4 мең кеше, 20 авыл советы, 114 торак пункт кала. 1972 нең 1 ноябреннән кайбер торак пунктлар яңадан оештырылган *Зәй районына* бирелә.

С.р. рельефы елга үзәннәре б-н бүлгәләнгән тигезлек (биеклеге 120–140 *м*); көньяк-көнчыгышында Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгы итәгенә барып тоташа (абс. биеклеге — 261 *м*). Минзәлә һәм кушылдыгы Игәнә елгалары ага. Җирләре күбесенчә селтесезләнгән һәм типик кара, көрән-соры, соры урман туфраклы. Саклаулы табигать истәлекләре: *Игәнә, Минзәлә* елгалары, *Бохарай нарат-лыгы, Сөлек урманы*. Терр-ясенең 5,9% ы — урманлык. Сәнәгать пр-тиеләре район үзәгеннән тыш шәһәр тибындагы Җәлил посёлогында («Җәлилнефть» НГДУ АҖ, «Мәлләнефть» АҖ) урнашкан. Районда нефть чыгарыла. Мөгезле эре терлек үрчетү алга киткән. А.х. җирләре — 108,4 мең *га*, ш.и. сөрүлекләр — 95,9 мең *га*. Көзге чәчүлекләрдән — арыш, бодай; язгылардан сабан бодае, язгы рапс үстерелә; шикәр чөгендере игелә. 2015 тә С.р.нда 24 крәстиян-фермер хуҗалыгы, аграр көллиятнең укыту (тәҗрибә) хуҗалыгы була. Район терр-ясеннән Чаллы–Әлмәт, Зәй–Сарман автомобиль юллары уза. 3 ф-ллы 24 гомуми белем бирү мәктәбе, (ш.и. 13 тулы булмаган урта, 11 урта), 35 мәктәпкәчә яшьтәгеләр учреждениесе; Бөек Ватан сугышы һәм төбәкне өйрәнү музее, сәнгать мәктәбе, музыка һәм сәнгать мәктәпләре, балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе, балалар техник иҗат үзәге, аграр көллият; 23 китапханә, 56 клуб, район үзәк хастаханәсе, участок хастаханәсе (Саклаубаш а.), дәвалау амбулаториясе (Александровка а.), 42 фельдшерлык-акушерлык пункты. Татар һәм рус телләрендә «Сарман» район г-тасы нәшер ителә.

**САРМА́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Кече Ирнә елгасының (Урман Зәе, Дала Зәе елгалары бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 14,5 *км*, бассейнының мәйданы 78,4 *км*$^2$. Зәй р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Сармашбаш авылыннан 4 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Ирнә авылыннан 0,5 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 220 *м*, тамагыныкы — 94 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. С.ның 0,8 дән 4,3 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,3 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 118 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,076 *м*$^3$*/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 12–20 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. С. бассейнында суының гомуми күләме 2,2 млн. *м*$^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**САРМАШБА́Ш** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 44 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Сармаш елгасы буенда. 2010 елда 337 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1735 тән Исаково исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә; игенчелек, терлекчелек, вак һөнәрчелек б-н шөгыльләнә, тирә-якtagы алпавыт утарларында көнлекчелектә эшли. 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышында* Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1320 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Яңа Спас волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1834 тә — 59 ир-ат (типтәрләр); 1859 да — 196, 1870 тә — 259, 1913 тә — 730, 1920 дә — 405, 1926 да — 470, 1938 дә — 542, 1949 да — 519, 1958 дә — 520, 1970 тә — 527, 1979 да — 466, 1989 да — 391, 2002 дә — 359 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**САРСА́З** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Эстәрле елгасының (Ык елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 13,6 *км*, бассейнының мәйданы 75,8 *км*$^2$. Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгы буйлап, Азнакай р-нында ага. Елга башы урман массивында, Октябрь Бүләге авылыннан 2,2 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Митрәй авылыннан 3 *км* көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 300 *м*, тамагыныкы — 101 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. С.ның 2,7 дән 10 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар, иң зурысы — Карамалы Елга (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,41 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 68 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренчеункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,02 *м*$^3$*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

**САРСА́З** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Минзәлә елгасының (Кама елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 11,6 *км*, бассейнының мәйданы 69,5 *км*$^2$. Сарман р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Сарысаз-Тәкермән авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Шәрләрәмә авылы янында. Елга ба-

шының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 92 *м*. Су җыелу мәйданында урман үсемлекләре үсми диярлек. С.ның 0,8 дән 2,5 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,23 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Елга җәен урыны-урыны б-н кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 91 *мм*, ташу агымы катламы 75 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,01 $м^3/с$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–700 *мг/л*.

**САРСА́З** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чилчә елгасы буенда. 2010 елда 37 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, иткә терлек асрау. Клуб, китапханә. Мәчет. 1922–24 тә Иске Тинчәле авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оештырылган көненнән ТАССРның Буа кантоны Иске Шәйморза волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1926 да — 555, 1938 дә — 687, 1949 да — 668, 1958 дә — 485, 1970 тә — 556, 1979 да — 555, 1989 да — 106, 2002 дә — 78 кеше.

**САРСА́З**, к. *Татар Сарсазы*.

**САРСА́З-БАГРА́Ж** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 19 *км* көнчыгыштарак, Баграж елгасының (Дала Зәе бассейны) сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 444 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 дән Починок Баграш, Сарысаз Тамак исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Баграж, Сарсаз-Тамак, Лысая Гора буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тәгәрмәч, чана ясау, чабата үрү, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1890 еллар башында ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1621 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 498, 1870 тә — 608, 1884 тә — 902, 1897 дә — 995, 1913 тә — 1268, 1920 дә — 1193, 1926 да — 1116, 1938 дә — 1092, 1949 да — 980, 1958 дә — 1061, 1970 тә — 1020, 1979 да — 705, 1989 да — 535, 2002 дә — 448 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**САРСА́З-БЛИ** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 9 *км* көньяктарак, Алан елгасы буенда. 2010 елда 61 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 1678 дән Сарыса исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, 2 су тегермәне эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1392,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Афанас волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1834 тә — 89, 1859 да — 114, 1870 тә — 412, 1897 дә — 644, 1920 дә — 837, 1926 да — 891, 1949 да — 643, 1958 дә — 471, 1970 тә — 346, 1979 да — 262, 1989 да — 107, 2002 дә — 94 кеше.

**САРСАЗТА́У** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 11 *км* көнчыгыштарак, Түбән Кама сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 7 кеше (руслар) яши. 1731 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, С.да 2 су тегермәне, 20 йөз башында земство мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1290,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Мәлкән волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1859 да — 517, 1870 тә — 534, 1884 тә — 1118, 1897 дә — 826, 1906 да — 864, 1913 тә — 1110, 1920 дә — 1155, 1926 да — 1048, 1938 дә — 688, 1949 да — 447, 1959 да — 427, 1970 тә — 311, 1979 да — 125, 1989 да — 20, 2002 дә — 18 кеше.

*Әд.:* Мензелинский край: История и современность. Мензелинск, 2006.

**САРСА́К** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Чаж елгасының (Иж елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 21 *км*, ТР чикләрендә — 8 *км*. Бассейнының мәйданы 96,6 *км*². Можга калкулыгы буйлап ага. Елга башы һәм югары агымы Удмурт Респ-касы терр-ясендә, тамагы Әгерҗе р-ны Сарсак-Умга авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. С.ның 0,7 дән 8,7 *км* га кадәр озынлыктагы 11 кушылдыгы бар, иң зурысы — Биер-Сарсак (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,54 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 87 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче унконлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,025 $м^3/с$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

**САРСА́К-ӘРӘМӘ́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 37 *км* көньяк-көнбатыштарак, Биер-Сарсак елгасы (Ижның бассейны) буенда. 2010 елда 3 кеше (руслар) яши. 1869 да нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Серсак исеме б-н дә билгеле. Халкы игенчелек, терлекчелек, балта эше, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 453,8 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Зур Кибә волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1887 дә — 178, 1905 тә — 263, 1920 дә — 381 (Куран авылы халкын да кертеп), 1926 да — 227, 1938 дә — 219, 1958 дә — 114, 1970 тә — 59, 1989 да — 9, 2002 дә — 8 кеше.

*Әд.:* Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**САРСА́К-УМГА́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 30 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чаж елгасы буенда. 2010 елда 606 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп-лицей, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөз ахырында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышында* Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында С.-У.да чиркәү (1904 тә төзелә), земство мәктәбе (1896 да ачыла), су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1928,2 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Зур Кибә волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1764 тә — 175, 1859 да — 388, 1887 дә — 638, 1905 тә — 704, 1920 дә — 880, 1926 да — 825, 1938 дә — 742, 1958 дә — 590, 1970 тә — 607, 1989 да — 632, 2002 дә — 594 кеше.

*Әд.:* Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**САРТА́К ХАН** (? — 1256), Алтын Урда ханы (1256). *Батый ханның* өлкән улы; тарихи хезмәтләрдә тәхет варисы буларак искә алына. Бүленмәс Монгол империясе тарафдары. Атасы вафатыннан соң Алтын Урда тәхетенә бөек каган Мөнке тарафыннан билгеләнә. Каракорымнан Идел буена кайтышлый юлда кинәт вафат була (Бәркә хан кешеләре тарафыннан агуланган дип фараз ителә); аның улы һәм варисы Улакчы да берничә ай идарә иткәннән соң үлеп китә. Новгород бөек кенәзе Александр Невский С.х. ярдәменә таяна (аны «туганым Сартак» дип атый).

Чыг.: Тизенгаузен В.Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. СПб., 1884. Т. 1; М.–Л., 1941. Т. 2.

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Сафарга-

л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; М ы с ь к о в Е.П. Политическая история Золотой Орды (1236–1313). Волгоград, 2003.

*И.Л.Измайлов.*

**САРУ́Т** (Elytrigia), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Ике ярымшарның тышкы тропик өлкәләрендә якынча 30 төре билгеле. Россиядә 10 төре билгеле. Татарстан терр-ясендә 4 есе үсә. Сирәк кенә далаланган сөзәкләрдә, күлчәсыман С. (E. loliodes), арадаш С. (E. intermedium) һәм бәссыман С. (E. pruinifera) очрый. Шуышма С. (E. repens) — иң киң таралган, озын, шуышма ак тамырчалы, шома ялангач сабаклы, биеклеге 130 *см* га кадәр һәм сызыклы яшел яисә күгелҗем яфраклы; вак, яшел чәчәкләре күп чәчәкле башакларда, ике рәт булып башакның үзәгенә урнашкан. Чәчәк төркеме — башак. Июнь–июльдә чәчәк ата, июль ахырыннан сентябрьгә кадәр җимеш бирә. Җимеше — бөртекчә. Бер үсемлек 500 *м* га кадәр тамырча барлыкка китерә һәм 10 меңгә кадәр бөртекчә бирергә сәләтле. Шуышма С. тамырында күпләп трицин углеводы, С витамины, аксым бар. Шуышма С.ның тамырыннан ясалган төнәтмәләр сидек һәм үт кудыру үзлекләренә ия; халык медицинасында сулыш юллары авырулары булганда кулланыла. Көтүлекләр өчен һәм печән булларак кыйммәтле үсемлек; су баса торган болыннарда 2 тапкыр чабып алуга 1 *га* дан 5–6 *т* печән бирә (100 *кг* да 50–60 азык берәмлеге, 5–6 *кг* үзләштерелә торган протеин бар). Шуышма С. — авыр бетерелә торган чүп үлән, туфракны бик нык киптерә һәм начарайта, аны эшкәртүне авырлаштыра; төрле корткычлар тарату чыганагы булып тора: чыбык личинкалары, яфрак төргечләр гусеницасы, кыяклылар чебене, бөртек ябалакчыклары, май коңгызы личинкалары. Шуышма С. б-н көрәш агротехник һәм химик юллар б-н алып барыла. Бәссыман С. ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Шуышма сарут.

*Әд.:* М а р к о в М.В. Злаки Татарской АССР. К., 1961; Б а к и н О.В., Р о г о в а Т.В., С и т н и к о в А.П. Сосудистые растения Татарстана. К., 2000.

*О.Л.Шайтанов.*

**САРЫ́ БАТЫ́Р** (? — 1554 тән соң), 1552–56 елларда Казан өчен барган азатлык сугышында катнаша. Отряды б-н Тау ягында хәрәкәт итә. 1553 нең язында С.Б. һәм Үсәен Сәет җитәкчелегендәге отрядлар Зөя каласы воеводасы Б.Салтыков гаскәри берәмлеген җиңүгә ирешә. Шуннан соңгы язмышы билгесез.


Чыг.: Полное собрание русских летописей. М., 2007. Т. 30.

*И.Л.Измайлов.*

**САРЫ́ БАШЛЫ́ КӘРЛӘ́ ТУРГА́Й** (Regulus regulus), кәрлә тургайлар семьялыгындагы кош. Евразия һәм Төньяк Америкада таралган. Россия орнитофаунасының иң кечкенә кошы. Гәүдәсенең озынлыгы 9–10 *см*, авырлыгы 5–8 *г*. Каурый капламы мамыктай йомшак, аркасы — зәйтүнсыман яшел, корсагы саргылт-ак төстә. Канатлары 2 аркылы аксыл сызыклы. Баш түбәсендә саргылт-кызыл бүрекчеге бар. Томшыгы нәзек, озын, кара төстә, томшык өсте төбендә бөгелгән. Кама алдының ылыслы һәм катнаш урманнарында оялый. Тирән, шарсыман диярлек ояларын чыршы ботаклары очында кора. Елга 2 тапкыр коңгырт чуар 8–12 аксыл-кызыл йомырка сала. Кош балалары май–июльдә чыга. Вак бөҗәкләр (гөблә, гусеницалар, үрмәкүчләр), аларның личинкалары, ш.у. чыршы һәм нарат орлыклары б-н туклана.

**САРЫ́ БУЯ́К** (Serratula), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 70 кә якын төре билгеле, Евразиядә, Төньяк Африкада таралган. Татарстан терр-ясендә 6 төре бар. Таҗлы С.б. (S. coronata) ара-тирә барлык районнарда таралган, калган төрләре сирәк очрый. Киң яфраклы урманнарда, куаклар арасында, болыннарда, далаланган тау битләрендә үсә. 30–150 *см* биеклектәге үсемлекләр. Сабагы гади яки тармаклы. Яфраклары чиратлашкан, каты, каурыйсыман-теленмә, тешле яки бөтен читле. Чәчәкләре көпшәле, ике җенесле; алсу, куе кызыл яки ак төстә. Чәчәк кәрзиннәре берле яки калкан чәчәк төркемендә. Җимеше — бүрекчәле озынча орлыкча. Июнь–сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре июль–октябрьдә өлгерә. Таҗлы С.б.ның җир өсте өлешендә С витамины бар; халык медицинасында үлән төнәтмәсе тамак, ашказаны авырулары вакытында кулланыла. Барлык төрләре дә — декоратив, баллы үсемлекләр. Буяу С.б. (S. tinctria), тармаклы С.б. (S. radiata), төрле яфраклы С.б. (S. lycopifolia), ялтыравык С.б. (S. cardunculus) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**САРЫ́ МӘТРҮШКӘ́** (Hypericum), ярабайчалар семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә берьеллык үләннәр, ярымкуаклар яки куаклар ыругы. Якынча 350 төре билгеле, Европа, Азия, Төньяк Америка һәм Төньяк Африкада очрый. ТР терр-ясендә 4 төре бар. Тишек яфраклы С.м. (H. perforatum) һәм тимгелле С.м. (H. maculatum) киң таралган. Төкле С.м. (H. hirsutum) һәм нәфис С.м. (H. elegans) күбесенчә Кама аръягында очрыйлар. Нигездә, урман аланнарында, куаклар арасында, болыннарда, далаланган тау битләрендә үсәләр. 15–100 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы туры, өске ягы тармаклы, очлы ике кырлы, төкле С.м.неке — 4 кырлы. Яфраклары каршыдаш, озынча — йомыркасыман, тишек яфраклы С.м.неке — күренеп торучы ноктасыман бизле, шунлыктан яфрак энә б-н тишкәләнгән кебек. Чәчәкләре алтынсу-сары төстә, берле яки күп санлы, себеркәч яисә калкан чәчәк төркеменә җыйналган. Җимешләре — күп санлы вак кара көрән орлыклы өч оялы тартмачык. Июнь–августта чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. С.м.нең җир өсте өлеше фәнни һәм халык медицинасында кулланыла. Сапониннар, алкалоидлар, флавоноид, эфир мае, кумарин, дуплау матдәләре бар. Төнәтмә һәм экстрактлары сулыш органнары, бавыр һәм ашказаны авырулары вакытында кулланыла. С.м. алкогольсез һәм ликёр-аракы эчемлекләрен хуш исләндерү өчен азык-төлек сәнәгатендә файдаланыла. Нәфис С.м. һәм төкле С.м. ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Тишек яфраклы сары мәтрүшкә.

*Әд.:* Б а к и н О.В., Р о г о в а Т.В., С и т н и к о в А.П. Сосудистые растения Татарстана. К., 2000.

**САРЫ́ ТАМЫ́Р**, к ө р м ә к (Limonium), сары тамырчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр, сирәк кенә ярымкуакчыклар ыругы. 300 гә якын төре билгеле, Евразия, Америка, Африкада таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — Сарепта көрмәге (L. sareptanum) бар. Кама аръягында очрый. Далаланган тау битләрендә үсә. 30–70 *см* биеклектәге куе төкчәле күпьеллык үсемлек. Яфраклары зур, чиратлашкан, тамыр яны таралгысына җыйналган. Чәчәкләре вак, саргылт-ак, зәңгәр, алсу касәле, чук чәчәк төркемендә. Җимеше коры, бер орлыклы, ачылмаучан. Июль–сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре август–октябрьдә өлгерә. Тамырчаларында дуплау матдәләре бар. Декоратив, баллы үсемлек. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**САРЫ́ ТӨНБОЕ́К**, т у ң г ы л ы к (Nuphar), төнбоекчалар семьялыгыннан күпьеллык су үсемлекләре ыругы. 10 нан артык төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. ТР терр-ясендә 2 төре бар. Гади С.т. (N. lutea) — ара-тирә барлык районнарда, вак С.т. (N. pumila) Көнчыгыш Кама алдында очрый. Агымсыз һәм әкрен агымлы сулыкларда үсәләр. Гади С.т.ның тамырчасы калын, итчел, С.т.ныкы — нечкә. Су өслегендә ятучы яфраклары йөрәксыман, йөрәксыман-озынча түгәрәк, калын, өсте ялтырап тора. Чәчәкләре берле, сары, озын чәчәк сапларында, төнгә ябылалар. Яфрак һәм чәчәк саплары тишекле-тишекле, һава каналлары б-н тыгыз бизәкләнгән. Үсемлекнең су асты органнарына шушы каналлар ярдәмендә сулау өчен кирәкле кислород керә. Яфрак яки чәчәк сапларын өзү үсемлеккә зур зыян китерә. Җимеше — итчел күп орлыклы яшел, шома тартмачык. Май ахыры – июльдә чәчәк аталар. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Тамырчасында — алкалоид, дуплау матдәләре, яфрак һәм орлыкларында органик к-талар бар. Халык медицинасында гади С.т.ның чәчәкләре, яфраклары һәм орлыклары төнәтмәсе гомумныгыту һәм бөер, бәвел юллары ялкынсынулары вакытында авыртуны басу ча-

расы буларак кулланыла. С.т. суүсемнәр һәм суга күмелгән үсемлекләрнең үсешен тоткарлый; биологик актив матдәләр бүлеп чыгарып, суның «чәчәк атуына» һәм анда патоген микроорганизмнар барлыкка килүгә каршылык күрсәтә. Гади С.т.ның тамырчасы — инсектицид; су күсесе, кондыз, җофар, су кошлары һ.б. өчен азык. Гади С.т. һәм вак С.т. — декоратив үсемлекләр. Ике төре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**САРЫ́ ЧЫПЧЫ́К** (Spinus spinus), тау чыпчыклары семьялыгындагы кош. Евразиядә таралган. Татарстан терр-ясендә ылысы һәм катнаш урманнарда яши. Идел һәм Кама үзәннәре буйлап оялау ареалының көньяк чиге уза. Күчмә кош. Апрельдән октябрьгә кадәр очрый. Чыршы, зирек, каен орлыклары мулдан булганда, бу кошларның шактый



өлеше ел дәвамында яши. Гәүдәсенең озынлыгы 11–13 *см*, авырлыгы 11–14 *г*. Ата затлар яшькелт төстә, күкрәге сары, бүксәсе ак, озынча канатлы, койрыгы аз гына уемтылы, кара, сары сызыклы; башы кара «бүрекчәле». Ана зат кара чуар соргылт-коңгырт төстә. Томшыгы конуссыман, кыска. Өскә һәм аска талпынып оча. Оялау чорында парлаша, ояларын чыршыларның, сирәк кенә нарат һәм каеннарның куе булып үскән өске ботакларында кора. Көрән тимгелле 3–6 зәңгәрсу йомырка сала. Орлыклар һәм бөҗәкләр (еш кына гөбләләр) б-н туклана. Элек-электән бүлмә кошы буларак билгеле.

**САРЫБА́Ш** (Crepis), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 250 гә якын төре билгеле, нигездә, Төньяк ярымшарда таралган. Татарстан терр-ясендә 5 төре бар. Чәйнәлгән С. (C. praemorsa), Себер какычасы (C. sibirica), япмалы С. (C. tectorum) барлык районнарда очрый, саз какычасы (C. paludosa) һәм венгр С.ы (C. pannonica) — сирәк төрләр. Киң яфраклы һәм катнаш урманнарда, куаклар арасында, карбонатлы тау битләрендә, болыннарда, сазлыкларда, юл буйларында үсә. 8–120 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы туры. Тамыр яны яфраклары бөтен, яфрак таралгысында, сабактагылары — кисек яки каурыйсыман-кисек. Чәчәкләре сары, кәрзиннәрдә урнашканнар. Җимеше — бүрекчәле орлыкча. Май ахыры – августта чәчәк ата. Җимешләре июль–октябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Декоратив үсемлек. Халык медицинасында Себер С.ы һәм япмалы С. үләненең төнәтмәсе ашказаны авырулары вакытында кулланыла. Саз какычасы ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**САРЫ́К АСРАУЧЫЛЫ́К**, терлекчелек тармагы. Сәнәгатькә — йон, тире, каракүл, сәүдәгә ит, сөт, сарык мае һ.б. җитештереп тапшыра. Продукциянең кайбер төрләре (нечкә эчәкләр, йон мае һ.б.) медицинада, парфюмерия сәнәгатендә киң кулланыла. С.а. дөньяның 150 дән артык илендә үсеш алган; продуктлылыгы төрле юнәлешле 1 млрд.тан артык сарык исәпләнә, генофондның җирле шартларга яраклаштырылган 600 дән артык токым тәшкил итә. Узган гасырның 60 нчы елларында СССР да сарыкларның 60 токымы асрала. Терлекләрнең баш саны һәм сарык ите җитештерү буенча ил дөньяда 1 нче, йон җитештерү буенча 2 нче урынны били. Татарстанда, башка күп кенә төбәкләрдәге кебек үк, С.а. тарихи нигып урнашкан тармак санала. 1913 елда Казан губернасында 1291,9 мең мөгезле вак терлек исәпләнә, ягъни 1 крәстиян хуҗалыгына 6,2 баш мал туры килә. Терлекчелектә җитештерелгән тулай продукциянең 38% ын С.а. тармагы бирә. 1926 да сарыкларның баш саны 2562,1 меңгә җитә, әмма сыйфат күрсәткечләре түбән була: тупас йонлы, озын яки кыска нечкә койрыклы җирле сарыкларның тереләй авырлыгы 45–70 фунт тәшкил итә, алардан 2–3 фунт йон кыркыла. 1932 дә колхозларда 34,3 мең башка исәпләнгән 110 сарык фермасы төзелә; 1935 кә фермалар саны — 904 кә, терлекләрнең баш саны 144,9 меңгә җитә.

1920 елларда, бериш нечкә һәм ярымнечкә йонлы кушылчак терлекләр китереп чыгаруны төп максат итеп куеп, нәселле терлек үрчетү буенча чаралар күрелә. 1921 дә Чистай өязенең Галактионово с-зында нәселле сарыклар фермасы булдырыла, фермага Германиядән прекос токымлы сарыклар сатып алына. 1932 дән колхоз-совхозларда массачыл рәвештә җирле *тупас йонлы сарыкларны* нечкә һәм ярымнечкә йонлы нәсел тәкәләренә йотылулы кушу юлы б-н токым яхшырту эше башлана; шәхси крәстиян хуҗалыкларында селекция-нәселле терлек үрчетү эше алып барылмый. 1934 тә Чистай р-ның «Урожай», «Мәгариф», Кукмара р-ның «Азлян», Балык Бистәсе р-ның «Марс» колхозларында (барлыгы С.а. б-н шөгыльләнүче 14 нәсел хуҗалыгында) нәселле терлек фермалары булдырыла. 1920–2000 дә җирле терлекләрнең продуктлылык һәм нәсел сыйфатларын яхшырту өчен 16 дан артык токымга караган, ш.и. черкас, совет мериносы, грозный, романов, прекос, мерино-фляйш, цигай, австралия мериносы, ромни-марш, острогожск, куйбышев, кавказ, алтай мериносы, красноярск, ставрополь, полварс токымлы сарыклар кертелә. Бөек Ватан сугышы елларында колхоз һәм совхозларда сарыкларның баш саны сугышка кадәргеге чор б-н чагыштырганда ике тапкыр кими һәм 283,3 мең тәшкил итә. 1952 дә сугышка кадәрге күрсәткечләрдән узып кителә: сарыкларның баш саны — 810 меңгә, 1960 та 909 меңгә җитә. Сарыкларның нәсел һәм токым сыйфатларын ясалма орлыкландыру юлы б-н яхшыртуга зур игътибар бирелә. 1970 тә колхоз-совхозларда чиста токымлы сарыклар — 154 мең баш, 1974 тә 536,9 мең баш була. Тупас йонлы сарыкларны нечкә йонлы тәкәләргә кушу буенча алып барылган дәвамлы эш нәтиҗәсе буларак, 1976 га респ-кадагы С.а. хуҗалыклары нигездә нечкә һәм ярымнечкә йонлы сарык асрауга күчеп бетә. Чиста токымлы сарыклар саны 94,7%, ш.и. прекос токымы 96,7, алтай мериноcлары 87,8, совет мериносы 98,4, куйбышев токымы 80,9% тәшкил итә.

1960–2000 елларда ТРда сарыкларның нәселен һәм продуктлылык сыйфатларын яхшырту һәм репродукция эше б-н 3 нәсел үрчетү совхозы — Азнакай р-ның Вахитов исем., «Урманай», Баулы р-ның «Кандыз» с-злары һәм 18 нәсел фермасы шөгыльләнә. Алардагы 43 мең баш терлеккә тулаем бонитировка уздырыла (100% тан элита классы — 17%, 1 нче классы — 32,3%, 2 нче классы — 22,4%, 3 нче классы һәм брак — 28,3%).

1975 тә сарык фермаларының һәркайсында уртача 1700 әр баш терлек асрала.

1980 еллар ахырында ТАССРның колхоз һәм совхозларында сарыкларның баш саны 800 мең исәпләнә, башлыча, нечкә һәм ярымнечкә йон юнәлешендәге сарыкларның 4 токымы асрала; прекос (73%), алтай мериносы (19%), куйбышев (4%), совет мериносы (3%), ш.у. мерин-фляйш (1%); шәхси крәстиян хуҗалыкларында (шәхси сектор) җирле тупас йонлы сарыклар тотыла.

Токымлы сарыклар саны арту нәтиҗәсендә, тулаем йон җыемы арта, йонның сыйфаты яхшыра. 1974 тә нечкә йон сату күләме 88%, ярымнечкә йон сату күләме 9,6% тәшкил итә. Шулай да, терлекләрне кушылдыру буенча массачыл эш башланудан алып, 2007 елга кадәр бер сарыктан кыркылган йон 2,5–3,4 *кг*, иткә тапшырылган терлекнең уртача тере авырлыгы 30–35 *кг* дәрәҗәсендә кала килә. Йон һәм ит буенча продуктлылык күрсәткечләренең түбән булуы сарыкларның токым сыйфатларын яхшырту эшенең терлекләрне ашату һәм карау шартларын яхшырту б-н бергә алып барылмавыннан чыгып аңлатыла, нәтиҗәдә, продуктлылык үсеше терлекләрнең токымын яхшырту темпларыннан калыша. Бәрәннәр үлеме аерым елларда респ-ка буенча тулаем 15% ка, кайбер районнарда 25–30% ка җитә һәм артып та китә. ТРда 2014 елда сарыклар саны 324000 баш тәшкил итә.

*Әд.:* Григорьев Н.В. Животноводство Татарии: Опыт, проблемы, перспективы. К., 1976; Фазульзянов А.Х., Минькин А.Ф. Интенсификация овцеводства Татарии. М., 1990; Мороз В.А. Овцеводство и козоводство. Ставрополь, 2002; Ульянов А.Н. Овцеводство. Краснодар, 2004.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**САРЫ́К ТИРЕСЕ́Н ЭШКӘРТҮ́ ҺӨНӘРЧЕЛЕГЕ́**, туннар тегү өчен тире эшләү һәм кыска туннар, толыплар, туннар һ.б. тегү. Сарык тиресен эшкәртү берничә этапта башкарыла. Башта аны өч көн яки аннан да озаграк вакытка суга салып җебетәләр, аннары агач калаклар б-н кырып чистарталар. Алдагы этап, тирене агач борыска беркетеп, чалгы пычак б-н мездрасын (тиренең эчке ягындагы йомшак ярыны) кырудан гыйбарәт була.

Эшкәртүнең шуннан соңгы этаплары берничә төрле ысул б-н башкарыла: 1) сарык тиресенә тоз ышкыйлар да 4 көнгә төреп куялар, аннары юып илиләр; 2) 3–4 көнгә әчеткегә — арыш оны кушып болгатылган суга батырып куялар; 3) камырсыман куе әчетке сылыйлар. Әчеткәннән соң тиреләрне изеп акбур сибәләр һәм илиләр. Иләү өчен яшь имән, тал яки зирек кайрысы кулланыла. Вакланган кайры өстенә кайнар су коялар, тиреләрне, шуның суынган эремәсенә салып, төнгә калдыралар, алып сыкканнан соң, араларына кайры сибеп чанга тутыралар һәм өсләренә эремә коялар. Чанда тиреләр өч көн тотыла, аларны даими рәвештә әйләндергәләп, эремәне алыштырып торалар. Иләнгән тиреләр киптерелә, кирәк дип табылган очракта, бөгәрләп изелә-йомшартыла, чалгы пычак б-н кырыла. 18–19 йөзләрдә С.т.э.һ. Казан губернасының Лаеш, Мамадыш, Зөя, Спас, Тәтеш һәм Чистай өязләрендә киң таралган була. Гадәттә, аерым гаиләләр шөгыльләнгән; вакытлыча ялланган кешеләр хезмәте дә файдаланылган. Эш, нигездә, заказга эшләнгән.

*Әд.:* Х а л и к о в Н.А. Хозяйство татар Поволжья и Урала (середина XIX — начало XX в.). К., 1995.

**САРЫМСА́К** (Allium sativura), суганчалар семьялыгыннан ике- һәм күпьеллык суганнар ыругыннан үләнчел үсемлек. Чыгышы б-н Көньяк һәм Көнчыгыш Азиядән. Культурада һәр җирдә таралган. Тамыр системасы чуклы. Яфраклары яссы, ланцетсыман, улаксыман, туры яисә бөгелүчән. Чәчәк сабагы (ук) тигез, биеклеге 60–150 *см.* Суганчасы катлаулы, 2–50 тешле, каты тиреле тәңкә б-н капланган. Ук җибәрә торган һәм ук җибәрми торган формаларга аерыла (аз ук җибәрә торган арадаш формасы да бар). Үстерү ысулы буенча көзге һәм язгы төрләре бар. Көзге С. ук җибәрә торган һәм ук җибәрми торган булырга мөмкин, киң яфраклы, язгы төренә караганда уңышы күбрәк, ләкин озак сакланмый. Язгы С., кагыйдә буларак, ук җибәрми, тар яфраклы, озак саклана. Чәчәк төркемендә 60–450 суганчыклар (бүлбечекләр) һәм шул ук санда чәчәк бөреләре барлыкка килә. Үрчетү өчен файдаланмаганда, укларны сындырып ташлыйлар, бу җир астындагы суганчаларның уңышын 20–40% ка арттыра. Суганчаларда 35–42% коры, 6–7,9% аксым матдәләр, 0,23–0,74% эфир майлары, С витамины, шикәр, полисахаридлар бар; С.ны кулинариядә тәмләткеч буларак һәм консервлауда кулланалар. Әчкелтем тәме һәм үзенчәлекле исе С.та аллицин эфир мае булуга бәйле, аңарда күп кенә авыруларга сәбәпче микробларны бетерүче фитонцидлар бар. Суганчыкларыннан һәм тешләреннән үрчетәләр. Язгы С.ны иртә язда, көзге С.ны салкыннар башланганчы тамырланып калуны исәпкә алып утырталар, тамырлары 0–5°С та тамыр җибәрә башлый; салкынга чыдам. ТР-да куллануга тәкъдим ителгән көзге С. сортлары: «Юбилейный грибовский», «Башкирский 85». Шәхси хуҗалыкларда үстерелә.



Сарымсак.

*Әд.:* Справочник по овощеводству. Л., 1982; К о к а р е в а В.А., Ю р ь е в а Н.А. Лук и чеснок на приусадебном участке. М., 1993; Овощеводство. М., 2003.

*Р.Ә.Әсретдинова.*

**САРЫМСА́К ҮЛӘНЕ́** (Alliaria), әвернә чәчәкләләр семьялыгыннан икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 5 төре билгеле, Евразиянең уртача поясында таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — яфрак саплы С.ү. (A. petiolata) бөтен җирдә дә очрый. Күләгәле урманнарда, куаклар арасында, ерымнарда, җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчаларында үсә. 25–100 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы туры, күксел куныклы. Яфраклары чиратлашкан, бөтен, түбәнгеләре — бөерсыман, озын саплы, өскеләре — йөрәксыман — озынча түгәрәк кыска саплы. Чәчәкләре вак, ак, чук чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — 4 кырлы кузакчык. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре июнь–июльдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Үсемлектән нык кына сарымсак исе килә (исеме шуннан). Үләнендә гликозид, С витамины, эфир мае, орлыкларында май бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе тир чыгару һәм какырык куптару чарасы буларак кулланыла. Яфракларын тәмләткеч буларак файдаланалар. Кәҗәләр өчен көтүлек азыгы булып тора.

**САРЫМСА́КОВ** Ширияздан Мөхәммәтҗан улы (29.4.1911, Акмола өлкәсенең Атбасар ш. — 1.10.1999, Казан), режиссёр, педагог, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1945, 1957). 1928–31 елларда Татар сәнгать техникумында (Г.Девишев курсы) укый. 1930 да Мәскәүдә узган СССР театрлары олимпиадасында Татар акад. театры спектакльләрендә катнаша. 1936 да Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тының (ГИТИС) режиссёрлык ф-тын (И.Я.Судаков, А.Л.Грипич курсы) тәмамлый һәм Татар акад. театрына режиссёр-сәхнәгә куючы вазифасына кабул ителә. Анда ул 1965 кә кадәр (1942–43, 1953–62 дә баш режиссёр) эшли. 1940–50 дә әйдәп баручы режиссёрларның берсе, татар театрында К.С.Станиславский карашларын эзлекле үстерүче, актёрлар б-н эшләгәндә дә, теге яки бу спектакльнең сәнгатьчә эшләнешен тәэмин иткәндә дә аның методологиясенә таяна, шул рәвешчә беренче чиратта тормыш дөреслегенә омтыла. Татар акад. театрында С. тарафыннан куелган «Шәмсекамәр» (М.Әблиев; 1938), «Тукай» (Ә.Фәйзи; 1939, 1942), «Таймасовлар» (Т.Гыйззәт; 1941) спектакльләре аның югары профессиональлеккә ия булуын, үз халкының тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен, этнографик үзенчәлекләрен тирәнтен белеп эш итүен раслый. Н.Ф.Погодин пьесасы буенча куелган «Мылтыклы кеше» (1947) спектакле театр тормышында күренекле урын тота. Т.Гыйззәт, А.Гыйләҗев, Ш.Шаһгали, Ә.Фәйзи, Ф.Хөсни кебек яшь драматурглар б-н актив эшләү дәверендә С. татар театры репертуарын баетуга зур өлеш кертә. Режиссёрның татар классикасына — Г.Камалның «Бәхетсез егет» (1955), К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» (1956,1962), «Җилкәнсезләр» (1958), Ф.Бурнашның «Таһир-Зөһрә» (1959) әсәрләренә — мөрәҗәгать итүе аның бу иҗатларны заманча күзлектән чыгып кабул итәргә омтылуы б-н аңлатыла. С. тарафыннан рус классикасы буенча куелган спектакльләр театр сәнгатендә зур бер вакыйга буларак кабул ителә. Алар арасында А.Н.Островскийның «Төшемле урын» («Доходное место», 1937), «Гаепсездән гаеплеләр» («Без вины виноватые», 1948), «Кичеккән мәхәббәт» («Поздняя любовь», 1950), М.Горькийның «Варварлар» («Варвары», 1946), «Соңгылар» («Последние», 1952) әсәрләре аеруча игътибарга лаек. С. ш.у. Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә куелган «Ирек» (комп. Н.Җиһанов; 1939), «Галиябану» (комп. М.Мозаффаров; 1940), «Тапшырылмаган хатлар» (комп. Ж.Фәйзи; 1960) спектакльләренең режиссёры була. 1944 тән Татар театр уч-щесендә һәм бер үк вакытта Казан консерваториясендә пед. эшчәнлек б-н шөгыльләнә, 1970–84 тә Казан мәдәният ин-тының режиссура һәм актёрлык осталыгы каф. профессоры. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1958).



Ш.М.Сарымсаков.

*Әд.:* И л я л о в а И. Театр имени Камала. К., 1986; А р с л а н о в М.Г. Татарское режиссёрское искусство (1941–1956). К., 1996; Театральная энциклопедия. М., 1965. Т. 4.

*И.И.Илялова.*

**САРЫСА́З-ТӘКЕРМӘ́Н** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Минзәлә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 236 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1710 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Тәкермән исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлек асрау, олаучылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1905,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Нөркәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Сарман р-нында. Халык саны: 1795 тә — 246 кеше, 1816 да — 161 ир-ат; 1834 тә — 208 асаба, 1859 да — 227 дәүләт крәстияне; 1870 тә — 837, 1897 дә — 1010, 1920 дә — 923, 1926 да — 787, 1938 дә — 627, 1949 да — 435, 1958 дә — 349, 1970 тә — 384, 1979 да — 297, 1989 да — 203, 2002 дә — 250 кеше.

**САРЬЯ́Н ХӘСӘ́Н**, к. *Хәсән Сарьян.*

**САСМА́К** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 24 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 261 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, китапханә. 1565–67 еллардан билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, умартачылык, он тарту, Казанда авыр йөк ташу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.та мәчет, мәктәп, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 615,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 104 ир-ат; 1859 да — 403, 1897 дә — 653, 1908 дә — 730, 1920 дә — 737, 1926 да — 696, 1938 дә — 640, 1949 да — 563, 1958 дә — 506, 1970 тә — 493, 1989 да — 345, 2002 дә — 275 кеше.

**САСНА́ ПҮЧИНКӘСЕ́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 25 *км* төньяктарак, Көшкәт елгасы буенда. 2010 елда 128 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Арбор волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1905 тә — 184, 1920 дә — 197, 1926 да — 193, 1938 дә — 233, 1958 дә — 153, 1970 тә — 126, 1979 да — 129, 1989 да — 117, 2002 дә — 128 кеше.

**СА́СОВО ТАТАРЛАРЫ́** (Бостан татарлары), Идел-Урал буе татарларының этно-терр. төркеме. Рязань өлкәсе Сасово р-нының Алёшина, Бостан, Зур Студенец, Теньсюпин, Тархан авылларында һәм Ставрополь краеның Төрекмән р-ны Куликовы-Копани авылында (Бостан авылыннан күченүчеләр) яшиләр. С.т. сөйләмнәре татар теленең урта диалектына карый, ләкин беркадәр фонетик үзенчәлекләргә ия. Диннәре — ислам (сөнниләр). С.т.ның милли үзенчәлекләре барлыкка килүдә җирле мишәрләр һәм нугай кабиләләре зур роль уйный. С.т.ның борынгы бабалары Рязань өлкәсе терр-ясендә якынча 12–13 йөзләрдә барлыкка килә. Төп шөгыльләре — игенчелек (19 йөздә С.т.ның зур өлеше дәүләт крәстияннәре катлавында була). 19–20 йөзләрдә С.т. арасында читкә китеп эшләү үсеш ала. Хәзерге вакытта аларның төп өлеше Бостанда яши; анда 2 мәчет (19 йөздә төзелә) эшли.

*Әд.:* Махмутова Л.Т. Бастанский говор татарского языка // Материалы по диалектологии. К., 1974. Т. 3; Исхаков Д.М. Татарская этническая общность // Татары. М., 2001.



К.Ш. Сатиев.

**САТИ́ЕВ** Кирам Шәйхиан улы (21.7.1955, Актаныш р-ны Татар Ямалы а.), баянчы, педагог, ТР-ның халык артисты (2006). 1979 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1981 дән Татар филармониясендә; бер үк вакытта, 2008 дән, Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында укыта. Концертмейстер буларак, Татарстан вокал сәнгатенең әйдәп баручы төп солистлары (И.Шакиров, Ә.Авзалова, Х.Бигичев, В.Гыйззәтуллина, Ф.Сөләйманова һ.б.) б-н чыгышлар ясый. 1989 дан соло программалары б-н Россиядә һәм чит илләрдә (Болгария, АКШ, Төркия) гастрольләрдә йөри, радио һәм телевидениедә чыгышлар ясый. Баян өчен әсәрләр: Баян һәм халык уен кораллары оркестры өчен концерт (1990), халык көйләренең эшкәртмәләре, пьесалар һ.б. авторы. Ф.Туишев исем. (1992) һәм И.Шакиров исем. (2005) музыкант-башкаручылар конкурслары лауреаты; халыкара һәм бөтенроссия конкурслары дипломанты. 2007 дән 2 елга бер тапкыр Татар Ямалы авылында С. исем. баянчылар һәм гармунчылар фестивале үткәрелә. С. музее ачыла (2007).

Хезм.: Татар баянчылары. К., 1996; Ак баян. К., 2005; Консерватория. Армия. Филармония. К., 2009.

**САТИ́РА** (лат. satira — «җыен юк-бар»), көлкенең бер төре, тасвирлау предметына карата авторның тиешле сәнгать чараларының һәм образларның гомуми характерын сайлауга тәэсир итә торган тискәре мөнәсәбәте. Сатирик көлү төрле формаларда (*ирония*, гипербола, гротеск, *фантастика*, *пародия*, инвектива һ.б.) һәм төрле жанрларда (*комедия*, *хикәя*, памфлет, карикатура, шарж һ.б.) бирелергә мөмкин. Татар әдәбиятында С. халыкның «көлү» культурасы тамырларына барып тоташа: татар йолалары һәм бәйрәмнәре көлке б-н кушылып бара, фольклор әсәрләрендә С. зур урын алып тора (шаян җыр, *мәзәк*, *табышмак*). Урта гасырлар татар әдәбиятында С. *кыйсса*, *мәсәл*, *хикайәт* жанрларына хас күренеш буларак яши. 19 йөздә С. мотивлары Г.Кандалый, Акмулла, Я.Емельянов, К.Насыйри һ.б.ның әсәрләрендә күзәтелә башлый. 19 йөз уртасыннан татар һәвәскәр театры үсеш ала, анда күбесенчә комедияләр куела. Г.Ильяси һәм Ф.Халидинең беренче пьесаларында милли патриархаль гаиләнең яшәү рәвеше тәнкыйтьләнә. Татар сәүдәгәрләре һәм байлары тормышын сатирик рәвештә тасвирлаучы мәгърифәтчелек прозасында З.Һади («Яңа әсхабе кәһәф» — «Яңа мәгарә кешеләре») һәм Ш.Мөхәммәдов («Япон сугышы, яхуд доброволец Батыргали агай») сарказм, ирония, гиперболага мөрәҗәгать итәләр.

20 йөз татар әдәбиятында Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Г.Камал, Г.Тукай, М.Гафури, Ш.Бабич иҗатларында С. аеруча көчле чагылыш таба. Мәгърифәтчелек идеалларын раслап, Ф.Әмирхан «Фәтхулла хәзрәт» сатирик повестенда феодаль тәртипләрдән көлә. Г.Исхакыйның «Тәгаллемдә — сәгадәт» («Бәхет — белемдә»), «Кәләпүшче кыз», «Бай угълы», «Өч хатын берлән тормыш», «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрләрендә, мәгърифәтчелек реализмы позициясеннән чыгып, әхлакый кимчелекләрне тәнкыйтьләү мыскыллы көлүгә әйләнә.

С. ярдәмендә Г.Тукай үз иҗатында милли яңарыш идеалларын раслый, искелеккә, арталыкка каршы көрәшкә өнди («Сорыкортларга», «Государственная думага», «Мөридләр каберстаныннан бер аваз», «Алтынга каршы», «Милләтче», «Золым», «Авыл халкына ни җитми?», «Сайфия», «Көзге җилләр», «Дөньяда торыйммы? — дип киңәшләшкән дустыма», «Ишан», «Ысулы кадимче»); аның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» сатирик поэмасы милләт язмышын кайгырту хисләре б-н сугарылган. М.Гафуриның мәсьәләләрендә, җәмгыятьнең иҗтимагый-сәяси төзелешеннән көлү б-н беррәттән, ш.у. әхлакый-дидактик эчтәлек тә урын алган («Үгез белән бүре», «Сарыкны кем ашаган?», «Эт белән куян»). Самодержавиене, феодаль тәртипләрне, дини фанатизмны тәнкыйтьләү Н.Думавиның беренче әсәрләрендә үк очрый, Г.Камалның «Беренче театр», «Бүләк өчен», «Безнең шәһәрнең серләре» пьесаларында төп көлке объекты — наданлык. Бу юнәлеш соңыннан Г.Коләхмәтов, М.Фәйзи, Г.Исхакый иҗатларында үсеш ала.

1920–30 еллар татар әдәбиятында сатирик башлангыч берникадәр сүлпәнәя, үгет-тәрбия яңгыраш ала. Драматургия (К.Тинчурин, «Җилкәнсезләр»; Н.Исәнбәт, «Һиҗрәт») һәм прозада (Г.Газиз, Г.Толымбайский хикәяләре) ул, фаш иткеч пафостан алып, хакимлек итүче идеологиянең мифлардан арынуына (Ф.Әмирхан, «Шәфигулла агай»), поэзиядә үзенә юнәлтелгән ирониягә (Һ.Такташ, «Гыйсъян», «Такташ үлде») кадәр үсә-үзгәрә бара. Бу елларда сатирик комедия жанры үсеш ала (К.Тинчурин, «Американ», «Портфель»). 1940–50 еллар С.сын бюрократияне үткен тәнкыйть утына тоткан, икейөзлелек, эчкерлелек, эчкечелекне, җәмгыятьнең башка кимчелекләрен фаш иткән сатирик шигырьләр, хикәя һәм комедияләр билгели. Фашизмга каршы юнәлтелгән әсәрләрдә С. яңа сулыш ала, гипербола, гротеск, шарж, күпертүләр ише сәнгать алымнарына иркен мөрәҗәгать итә.

1960–80 еллар татар сатирик әдәбияты үсешендә яңа этап булып тора. Язучылар актив рәвештә «яшерен көлү» осталыгын үзләштерәләр, С. чаралары б-н тормышны эпик киңлектә тасвирлау чикләрен киңәйтәләр (А.Гыйләҗев, Ф.Хөсни, И.Гази, Хәсән Сарьян). Әхлакый характерларны, замана җимеше булган үзенчәлекле социаль типларны тергезү омтылышы күзәтелә башлый (Хәсән Сарьян, «Нокталы өтер», «Бер ананың биш улы»; А.Гыйләҗев, «Әтәч менгән читәнгә»). Кеше күңеленең «саегуы» темасын типик ясылыкта Ф.Шәфигуллин ачып бирә. Шигъри С. да үсеш ала. Поэзиядә иҗтимагый-психол. гротеск, фәлсәфи-аналитик башлангыч көчәя (Ә.Исхак, Г.Афзал, Ш.Галиев). С. әдә-

би процессның үзен анализлауга тартыла, шуның б-н пародия һәм эпиграмманы яңартуга этәргеч бирә.

20–21 йөзләр чигендә совет чоры (язучылар кешенең тоталитар системада яшәве проблемасына мөрәҗәгать итәләр) һәм совет чорыннан соңгы вазгыять тәнкыйди тикшерү объектына әверелә. Җәмгыятьтә һәм замандашлар күңелендә тотрыклылык югалу проза әсәрләрендә ешрак сизелә һәм ирония, сарказм, әдәби уен ярдәмендә тәкъдим ителә (Ф.Садриев, «Бәхетсезләр бәхете»; Т.Галиуллин, «Сәет Сакманов»; Р.Мөхәммәдиев, «Кенәри — читлек кошы»; Г.Ахунов, «Этләр патшасы»). Авторларның совет идеологиясен мифлардан арындыру, «абсурд» дөнья картинасын булдыру омтылышы С.ны концептуаль дәрәҗәдә файдалану б-н бергә үрелеп бара (прозада — З.Хәким, «Агымсуда ни булмас»; М.Кәбиров, «Сары йортлар сере»; драматургиядә — Ф.Бәйрәмова, «Вакыйга җүләрләр йортында бара»; Д.Салихов, «Алла каргаган йорт»; З.Хәким, «Җүләрләр йорты»). Әлеге әсәрләрнең поэтикасын күп очракта әдәби уен ысулы билгели. Т.Миңнуллинның «Минһаҗ маҗаралары» романында пародия-гротеск формасында массалар аңында яшәп килгән мифлар тасвирлана, милли тарихны кабат күздән кичерү омтылышы ясала. Аның драматургиясендә («Әлдермештән Әлмәндәр», «Сөяркә», «Илгизәр+Вера») милләтне саклап калу һәм яңарышка чакыру проблемасы сатирик алымнар һәм чаралар ярдәмендә калкуландырыла. Поэзиядә С. һәм юморның үрелеп баруы күзәтелә, бу үз чиратында карикатуралаштыру, җиңелчә көлү, мәгънәви каламбур тудыра (Ш.Галиев, Л.Лерон, Р.Миңнуллин, Л.Шәех). Сынлы сәнгатьтә С. *графика* һәм *плакат* жанрларында үсеш ала.

*Әд.:* Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. К., 2007; Ганиева Р.К. Сатирическое творчество Габдуллы Тукая. К., 1964; Ханзафаров Н. Татарская комедия. К., 1996; История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX вв.). К., 2003.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**СА́ТКА РАЙОНЫ́**, *Чиләбе өлкәсенең* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1926 елның 4 ноябрендә оештырыла. Мәйданы — 2397 *км*². Үзәге — Сатка шәһәре (Чиләбедән 236 *км* көнбатыштарак). Халкы — 83311 (2013), татарлар — 10303 кеше (2010). Татарлар, тупланып, Сатка, Бакал шәһәрләрендә, Сулея посёлогында яшиләр. Бакал шәһәренең «Горняк» мәдәният сарае каршында милли татар-башкорт (1964 тән), Сатка шәһәренең «Магнезит» мәдәният сарае каршында «Җәйгор» татар-башкорт сәнгать (1986 дан; 1997 дән — халык) коллективлары эшли. Саткада 1994 тән Татар-башкорт мәдәнияте үзәге эшли, аның каршында 1995 тә гарәп телен өйрәнү сыйныфы ачыла; 2003 тә әдәби иҗат берләшмәсе оештырыла. 2004 тә Сатка шәһәренең 2 урта мәктәбендә һәм Сулея посёлогы урта мәктәбендә татар, башкорт телләрен өйрәнүче факультатив сыйныфлар эшли.

**САТЛЫГА́Н** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 46 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шомбыт елгасы буенда. 2010 елда 42 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп. 1680 нән Шиһазда Пучинкәсе буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Салтыган Чаллысы исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 238 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Мамадыш кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 20 ир-ат; 1859 да — 124, 1897 дә — 235, 1908 дә — 252, 1920 дә — 321, 1926 да — 273, 1938 дә — 283, 1949 да — 253, 1958 дә — 242, 1970 тә — 245, 1989 да — 118, 2002 дә — 73 кеше.

**САТМЫ́Ш** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 28 *км* төньяктарак, Казан–Ульянов автомобиль юлы буенда. 2010 елда 321 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1647–52 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.та мәчет, мәдрәсә, 2 җил тегермәне, 2 кечкенә кибет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 832 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ивановка волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында, 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 60 ир-ат; 1859 да — 554, 1897 дә — 1074, 1908 дә — 1138, 1920 дә — 969, 1926 да — 803, 1938 дә — 751, 1949 да — 702, 1958 дә — 652, 1970 тә — 544, 1979 да — 476, 1989 да — 399, 2002 дә — 352 кеше.


**САТТА́Р** (Саттаров) Ил Рәхим улы (10.2.1933, БАССРның Учалы р-ны Учалы а. — 21.4.2001, Казан; Биектау р-нының Биектау авылында җирләнә), публицист, философ, филос. фән. канд. (1986). Казан ун-тын тәмамлый (1960). 1961 елдан Халык иҗаты йортында репертуар методисты булып эшли. 1965 тән Казан архит-ра-төзелеш ун-тында укыта. Вакытлы матбугатта төрле елларда дөнья күргән публицистик мәкаләләр авторы (соңрак «Пәйгамбәрлек» («Прозрение», 2003); «Милләт алга барамы, әллә чигенәме?» (2007); «Хакыйкатъ эзләү» («Поиск истины», 2009) җыентыкларына керәләр). Аларда авторның татар халкының үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында уйланулары, аның язмышы хакында борчылулары чагылыш таба. Фәлсәфи хезмәтләре эстетика һәм сәнгать нигезләренә, кеше холкының асылына һәм сәнгать проблемаларына багышлана .

Хезм.: Эстетика. К., 2002; Фәлсәфә: 2 китапта. К., 2000–03; Философские записки. К., 2009; Объективные основы эстетического сознания. К., 2009.

**САТТА́Р** (Габделсаттаров) Рәхим (Габделрәхим) Сөләйман улы (15.8.1912, хәзер БРның Чишмә р-ны Түбән Хаҗәт а. — 1943), шагыйрь. 1939 елдан соң Казанда, «Яшь сталинчы» г-тасы редакциясендә эшли. 1941 нең көзендә сугышка алына, 1942 нең июнендә әсирлеккә төшә. Вустрау фашистлар лагеренда «*Җәлилчеләр төркеме*» әгъзасы була. 1943 нең июнендә лагерьдан кача. Алдагы язмышы билгесез. 12 яшьтән яза, вакытлы матбугатта басыла башлый. Сугыш елларында язылган мәхәббәт, Ватан, тугрылык турындагы «Ант», «Әнкәмә хат», «Әсирләр», «Халкым өчен», «Бүленгән җыр» шигырьләре «Җыр дәвам итә» (1966), «Өч көрәшче шагыйрь» («Три поэта-воина», 1979) исемле коллектив җыентыкларга кергән.

Әсәр.: Безнең буын. К., 2006.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.



Г.Ф. Саттаров.

**САТТА́РОВ** Айвар Гомәр улы (5.5.1956, Төмән өлкәсе Тубыл ш.), архитектор, педагог, архит-ра фән. канд. (1985), ТРның атказ. архитекторы (2006). Мәскәү архит-ра ин-тын тәмамлаганнан соң (1979), Казан архит-ра-төзелеш ун-тында укыта; 2000–10 да архитектур мирасны реставрацияләү һәм реконструкцияләү каф. мөдире. Бер үк вакытта, 1979 дан, архит-ра-проектлау остаханәсе б-н җитәкчелек итә. С. проектлары буенча Казан Кремлендә Колшәриф мәчете ансамбле (1997–2005, автордаш, шәһәр төзелеше чишелеше һәм мәчет интерьерларының сәнгати-декоратив бизәлеше авторы, 2012 дә ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге бирелә), Тукай р-нының Шәңгәлче авылы мәчете (2006), Казакъстанның Актүбә шәһәрендә «Нургасыр» мәчете (2008), Башкортстанның Эстәрлетамак р-нында «Суфия» мәчете (2008) төзелә. РФнең СА (1989) һәм ТРның Рәссамнар берлеге әгъзасы (2000). Казакъстан Респ-касының 2 нче дәрәҗә «Дуслык» ордены б-н бүләкләнә.

**САТТА́РОВ** Гомәр Фәез улы (2.7.1932, Норлат р-ны Мулла Иле а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (1976), проф. (1981), ТССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1991, 2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1955), Тубыл пед. ин-тында эшли. 1962–2011 елларда Казан ун-тында, 1994–99 да татар теле каф. мөдире. Татар ономастикасына нигез салучыларның берсе. Хезмәтләре төрки-татар оно-



Р.С. Саттаров.

мастикасы, ономастик лексикография, топонимика һәм лексикология, татар халкы этногенезына карый. Урта мәктәпләрдә татар теле укыту методикасына караган хезмәтләр авторы. «Татар топонимиясе» монографиясе (1998) өчен ТРның Фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт бүләге бирелә (2002). Казан ун-тының атказ. проф. (2010). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Татар исемнәре ни сөйли? К., 1998; Татар телен урта мәктәптә һәм гимназияләрдә укыту методикасы. К., 2002.

*Әд.:* Тюркологи современного Татарстана. М., 1997; Гомәр Фәез улы Саттаровка 75 яшь // Фән һәм тел. 2007. № 3.

**САТТА́РОВ** Мансур Маннур улы (31.12.1948, Казан), нәкышьче, график, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2005), халык рәссамы (2011). Уфа сәнгать уч-щесен тәмамлый (1968). 1976 елдан Мәскәүдә яши. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1977). 2000 нән Мәскәүдәге «Рәссам» татар-башкорт рәссамнарының иҗат берлеге вице-президенты. Париж халыкара «AJSAP» фән һәм сәнгать академиясенең хакыйкый әгъзасы (2008). Халыкара язучылар һәм публицистлар ассоциациясе әгъзасы (Рига, 2007). С.ның иҗат потенциалы портрет жанрында тулы ачыла; ш.у. пейзажлар, натюрмортлар, сюжетлы картиналар өлкәсендә нәтиҗәле эшли, аларга иҗади күрү үзенчәлеген өсти. С.ның сәнгать теле стилендә 2 төп тенденция ачыла: романтик рух, саргылт-кызыл төсмерләр өстенлек иткән якты төсләр палитрасы файдаланылган җиңел, орфия һавалы нәкышь; фотореализм элементлары булган, төсләр һәм фактура б-н баетылган нәкышь. Майлы буяу һәм темпера б-н эшли. Уфа чорына караган



М.М. С а т т а р о в. «Зур театр балеринасы Л.Н.Зотикова портреты». 1988.

беренче әсәрләре (1970 еллар), башлыча, тематик картиналар («Балачак турында хатирәләр» сериясе, 1971–76), портрет («Актёр Е.Логвинов», 1978; «Саңгырау рәссам», 1979), пейзаж («Борынгы Рига», «Апрель», икесе дә — 1975), пейзаж-натюрморт (кошлар сериясе), натюрморт (чәчәкләр һәм «кипкән букетлар» сериясе, 1976) жанрларында иҗат ителгән. С.ның Заполярье табигатенең кырыс һәм романтик гүзәллеген чагылдырган 1980 еллар пейзажлары («Арктика», «Диксон. Җәй», «Карск диңгезе яры», 1986–89) экспрессионизм стилендә башкарылган. Шул ук елларда геологларның, газ сәнәгатендә эшләүчеләрнең, төзүчеләрнең кыю образлары гәүдәләндерелә («Командор», 1981; Уренгой–Помары–Ужгород газ үткәргече эшчеләре Р.Саттаров, В.Можаров, Х.Газизов һ.б.ның портретлары циклы). Соңрак С. Швеция, Дания, Исландиядә була, «Атлантиканың бозлы утраулары» циклын, «Исландия айсберглары» сериясен иҗат итә (икесе дә — 1997). 1980 еллар ахырында рәссам пейзаж фонында гәүдәләнгән портрет һәм ялангач хатын-кыз натурасына мөрәҗәгать итә («Якты өметләр образы», 1989; «Ялгыз акчарлак



М.М. С а т т а р о в. «Идел иртәсе». 2002.

авазы», 1991). Дәүләт һәм сәясәт эшлеклеләре портретларын иҗат итә: Дания королевасы Маргрете II, Россия премьер-министры В.С.Черномырдин (икесе дә — 1997), Мисыр Президенты Х.Мөбарәк (1999), Россия Президенты В.Путин (2002), РФ Мөселманнарының Диния нәзарәте мөфтие Р.Гайнетдин, Франция Президенты Ж.Ширак (икесе дә — 2004), Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев (2005, 2006) һ.б. Натурадан төшерелгән портретлар (балерина Л.Н.Зотикова, 1988; хатыны, 1991; җырчы Диларом, кардиохирург Р.Акчурин, 2000 еллар һ.б.) авторы. С.ның станлы графикасына карандаш б-н ясалган рәсемнәре («Шәрекъ аһәңе», «Шаморгта җәй», икесе дә — 1996; «Улым белән хатыным портреты», 2001) керә.

Бөтенроссия — «Совет Россиясе» (Мәскәү, 1975); халыкара — Швеция (1981), Тунис (1984), Венгрия (1985), Франциядә (1999–2001) рус сәнгате; «Мәскәү — тынычлык шәһәре» халыкара сынлы сәнгать (2003–06) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Мәскәүдә (1979–2005 тә 10 күргәзмә), Штутгартта (Германия, 1985, 1988), Хельсинкида (Финляндия, 1988, 1989, 1990, 1996), Казанда (1988, 2005, 2011), Стокгольмда (Швеция, 1989), Мюнхенда (Германия, 1992), Женевада (Швейцария, 1993) һ.б.да уздырыла.

Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, М.В.Нестеров исем. Башкорт сәнгать музеенда, Владивосток, Коньяк Сахалин картиналар галереяларында, Россиядәге һәм чит илләрдәге шәхси тупланмаларда саклана. С. Дали исем. Бөтендөнья альянсының алтын медале (Испания, 2007), Халыкара иҗат академиясенең Н.И.Сац алтын медале (2009), М.Ломоносов, Изге бөек кенәз Дмитрий Донской һәм изге игумен Сергий Радонежский, 3 нче дәрәҗә Бөек Пётр, «Малахит йолдыз» орденнары б-н бүләкләнә; Европа сәнгать берлегенең «Көмеш тәлинкә» призы иясе (Прага, 2008).

*Әд.:* Р т и щ е в а Л. С юношеской увлечённостью // Художник. 1977. № 1; К а р п о в В. Открытый мир Мансура Саттарова // Наш изограф. 2001. № 4; Мансур Саттаров. Открытый мир: Альбом. М., 2006.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**САТТА́РОВ** Равил Зәйтүн улы (22.9.1968, Бөгелмә ш.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007), техник фән. канд. (2007). Кама политехник ин-тын тәмамлый (Чаллы ш., 1993). ТатНИПИнефтьтә эшли, лаб. мөдире (2004 тән). Хезмәтләре нефть чыганаклары запасларын исәпләү һәм эшкәртүнең информацион технологияләренә карый. Дәүләт бүләге автоматлаштырылган проектлау технологияләре нигезендә нефть чыганакларын эшкәртү алымнарын булдыруда һәм сәнәгатьтә кулланышка кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**САТТА́РОВ** Рәшит Саттар улы (12.10.1912, Самара губ., Бөгелмә өязе Мәмәт а. — 27.11.1996, Әлмәт ш.), ташчы, Соц. Хезмәт Герое (1958), ТАССРның атказ. төзүчесе (1972). 1930–32 елларда Үзбәкстан ССРның Пахта р-нында бакчачылык совхозында эшли. 1932–38 дә Әлмәт р-нының «Победа» к-зында, 1938–40 та Бөгелмә р-нының «Батуринка» к-зында тракторист-машинист. 1946–51 дә Казакъстан ССРның Җамбул өлкәсе «Чустрой» участогында ташчы. 1951–72 дә «Татнефтестрой» комб-тындагы 8 нче төзелеш-монтаж трестының 42 нче төзелеш-монтаж идарәсендә (Әлмәт), ташчылар бригадиры (1953 тән). Герой исеме төзелештә югары нәтиҗәләргә ирешкәне өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Әлмәт шәһәренең мактаулы гражданы (1969); шәһәрнең төбәк музеенда С.ның тормышы һәм эшчәнлегенә багышланган стенд, Геройлар аллеясында С. бюсты куелган.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Әлмәт — Альметьевск. К., 2003.

**САТТА́РОВ** Феликс Габделнур улы (3.3.1948, Әтнә р-ны Түбән Көек а.), физик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1998), физика-матем. фән. канд. (1984). 1971 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Федераль ГИПО ФҖБ Дәүләт унитар пр-тиесендә эшли, сектор (1988–98, 2006 дан), бүлек (1998–2006) башлыгы. Хезмәтләре күләмле һәм рельефлы-фазалы голограммалар алу технологиясенә, аларны оптик элементлар сыйфатында тикшерүгә карый. Уйлап табуга 18 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге голограммалы дифракцион

рәшәткәләр әзерләүнең фәнни технологиясе нигезләрен эшләүдә һәм аны ГИПОның сериәләп дифракцион оптика җитештерүенә кертүдә катнашканы өчен бирелә (Россия тармак пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән). СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

**САТТА́РОВ** Шәриф Шәриф улы (10.5.1887, Оренбург ш. — 1972, Яшел Үзән ш.), драматург. Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлаганнан соң (1909), *Буби мәдрәсәсендә* рус теле укыта. 1911 дә «*Бубилар эше*» буенча кулга алына. 1911 нең маеннан 1913 нең сентябренә кадәр Казанда полиция күзәтчелеге астында яши. 1913 тә Вятка губернасына китә, «Буби» мәдрәсәсендә эшли, Иж-Байки авылында укыта (1914–15). 1915–17 дә Рус Каргаш уч-щесендә (Әстерхан губернасының Сәетле а.) укыта. 1917 нең сентябреннән рус-татар уч-щесе мөдире (Әстерхан ш.), Әстерхан губернасының халык мәгарифе органнарында җитәкчелек эшендә. 1923–24 тә укытучылар һәм эшчеләр курсларында укыта (Баку). 1925–50 дә Мәскәүдә яши, Мәскәү халык мәгарифе органнарында җәмәгать инспекторы вазифаларын башкара, вакытлы матбугатта хезмәттәшлек итә. 1950–55 тә — Ташкентта, 1955 тән — Яшел Үзәндә. «Бәхетсез татар кызы» (1911), «Татар тәгассыб вә җәһаләтенең корбаны» (1911), «Азатлык корбаннары» (1919) һ.б. пьесалар авторы. Кайбер пьесалары Казан һәм Әстерхан театрларында куела.

Х е з м.: Эш һәм белем: Әлифба. М., 1926 (автордаш); Кызылармеец: Кызылармеецлар һәм допризывниклар өчен эш китабы. М., 1931.

*Әд.:* Р ә м и И., Д а у т о в Р. Әдәби сүзлек. К., 2001; Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Библиогр. сүзлек. К., 2005.

**САТТА́РОВА** Камал (Васфикамал) Мәгъсүм кызы (30.7.1923, Арча кантоны, хәзер Биектау р-ны Торнаяз а. — 10.10.1985, Казан; туган авылында җирләнә), радио дикторы, ТАССР һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1966, 1977). 1941 елда Казанда урта мәктәп тәмамлый. 1943 нең февраленнән 1981 нең ноябренә кадәр ТАССР телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт ком-ты дикторы, бернечә тапшыруның алып баручысы. Казан кинохроника студиясенең документаль фильмнарына тавыш яздыруда катнаша. Татар телендәге радиотапшырулар үсешенә зур өлеш кертә. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Тыңлагыз, Казан сөйли! — Слушайте, говорит Казань! К., 1998.

**САТТА́РОВА** Флёра Фәтхерахман кызы (29.9.1938, Арча р-ны Урта Бәрәзә а. — 19.4.1991, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1986), проф. (1990). Казан пед. ин-тын тәмамлагач (1962), шунда ук филос. һәм фәнни коммунизм (1966–69), КПСС һәм фәнни коммунизм тарихы (1969–76), фәнни коммунизм (1976 дан) кафедраларында эшли. Хезмәтләре 20 йөздә Идел буе һәм Урал төбәгендә профсоюз хәрәкәте тарихына багышлана.

Х е з м.: Школа коммунизма: Профсоюзные организации автономных республик Поволжья и Приуралья в период социалистического и коммунистического строительства. К., 1983.

*Е.Б.Долгов.*

**САТЫ́ЕВ** Бари Хәбиб улы (19.10.1937, БАССРның Миякә р-ны Кыргыз-Миякә а.), ат үрчетү белгече, а.х. фән. д-ры (1989), проф. (2006). Башкорт а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Уфа колхоз-совхоз җитештерү идарәсендә инженер-оештыручы. 1965–2000 елларда (бүленеп) Башкортстан терлекчелек һәм терлек азыгы җитештерү фәнни-тикшеренү һәм проект-технология ин-тында: ат үрчетү бүлеге мөдире, баш фәнни белгеч, ат үрчетү лаб-ясе мөдире (1996 дан). 1978–84 тә Бөтенсоюз нәсел үрчетү фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү). Атларда канның антиген факторларын ачыклау өчен сыгынты-реагентлар ясау методикасын, колыннарның нәселе турындагы язмаларның чынбарлыкка туры килүенә иммуногенетик контроль үткәрү ысулларын эшли, атларның итлелек һәм сөтлелек сыйфатларына иммуногенетик маркерларны ачыклый; балалар өчен һәм диетик туклану максатларында экологик чиста ат ите җитештерүнең технологик алымнарын теоретик яктан нигезли; башкорт токымлы атларның итлелек сыйфатын яхшырту юнәлешендә эш алып бара. Хезмәтләре башкорт токымлы ит атларының заводта үрчетелүче төрләрен барлыкка китерү өчен нигез булып тора, шуның нәтиҗәсендә ат итен җитештерү 14–16% ка арта. БРның Учалы р-нында атларның учалы төрен үрчетү б-н шөгыльләнүче 2 нәсел з-ды бар. С. уйлап табуга 2 патент һәм 2 авторлык таныклыгына ия. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Табунное коневодство. Уфа, 1985 (автордаш); Башкирская лошадь. Уфа, 1988 (автордаш); Коневодство Башкортостана. Уфа, 2001 (автордаш).

**САТЫЛГА́Н** (?–1506), Касыйм ханы (1491 елдан). *Нурдәүләт хан* улы. Атасы вафатыннан соң тәхеткә утыра. 1491 елдан Казан ханы Мөхәммәдәмин һәм Кырым ханы Миңлегәрәй б-н бергә Олы Урданың дала як олысларына яу чабуда катнаша. С. дәверендә Касыйм ханлыгы сәяси мөстәкыйльлеген чагыштырмача саклый, Рязань кенәзлеге җирләреннән табыш, Мәскәүдән бүләкләр һәм түләүләр ала. Казан б-н сугыш вакытында (1505–07) рус гаскәрендә татар атлы полкы б-н җитәкчелек итә, Мөхәммәдәмин гаскәренең Муром шәһәренә һөҗүмен кире кайтара.

*Әд.:* В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1863–64. Ч. 1–2; Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923.

*И.Л.Измайлов.*

**САТЫ́П АЛУЧЫ́-КУЛЛАНУЧЫЛА́Р КООПЕРА́ЦИЯСЕ**, гражданнарның, юридик затларның сәүдә, әзерләүләр, җитештерү һ.б. максатларында пай взнослары нигезендә оештырылган ирекле берләшмәсе. Татарстанда Татарстан кулланучылар җәмгыятьләре берлегенә (Татпотребсоюз, 1993–2006 елларда «Татреспотребсоюз») керүче 36 район кулланучылар җәмгыятьләреннән (райпо), 4 кулланучылар берлегеннән (райпотребсоюз) гыйбарәт. Пайчылар саны — 34,7 мең кеше, ш.и. С.а.-к.к. системасында эшләүчеләр — 9,1 мең кеше. Тулай товар әйләнеше күләме — 4 млрд. сум (респ-ка товар әйләнешенең 2% чамасы), ш.и. ваклап сату — 2,8 млрд. сум,



К.М. Саттарова.

җәмәгать туклануы — 238 млн. сум. Әзерләүләр әйләнеше — 465 млн. сум. С.а.-к.к. үзенең эшчәнлеген, башлыча, авыл җирендә гамәлгә ашыра. 2086 ваклап сату пр-тиесе, ш.и. 100 мең $м^2$ мәйданда 2061 кибет эшли. Татарстан кулланучылар җәмгыятьләренә ш.у. «Коопторг» кулланучылар җәмгыяте керә, ул Күмәртәле сәүдә б-н шөгыльләнә: авыл җирендәге кулланучылар җәмгыятьләрен товарлар б-н тәэмин итә. ТРда ш.у. пай взнослары нигезендә кредит, сату, тәэминат, торак, гаражлар төзү, а.х., бакчачылар, кәсепләр, ремонт һ.б. кулланучылар кооперативлары эшли.

Казанда кулланучыларның тәүге җәмгыятьләреннән берсе 1868 дә барлыкка килә, аның 3 сәүдә лавкасы, икмәк пешерү урыны була, үзенең әгъзаларына (40 кеше) ташламалы шартларда төрле куллану предметлары (утын, күмер) сата, төрле хезмәт күрсәтүләр (мунчалар, китап төпләү) б-н шөгыльләнә. Пай взносы елга 5 сум тәшкил итә. 1870 тә җәмгыять банкротлыкка чыга һәм яшәүдән туктый. Спас-Затон кулланучылар җәмгыяте (1868 дә оеша) суднолар ремонтлау з-ды эшчеләрен берләштерә (кооператив эшчәнлегендә алар пай взнослары һәм үзләренең хезмәтләре б-н катнашалар). 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Казанда, аннары өязләрдә яңа кулланучылар җәмгыятьләре, ш.и. Казанда Алафузовлар завод-фабрикаларының сәүдә-сәнәгать ширкәтенең җитен эрләү-туку мануфактурасы һәм күн з-ды каршындагы кулланучылар җәмгыяте (1897) барлыкка килә. Җәмгыятьнең 187,6 мең сум еллык әйләнешле лавкасы, елга 33 мең пот чамасы икмәк пешерүче икмәк пешерү урыны була; пайчылар саны 481 кеше тәшкил итә (1909). Беренче бөтендөнья сугышы елларында Казан губернасында авыл кулланучылар кооперативлары (Тәтеш өязенең Чирү авылында, Чистай өязенең Биләр, Татар Баганалысы авылларында) оеша. Кооперативларның саны тиз темплар б-н үсә. 1916 да Казанда Кулланучылар җәмгыятьләре берлеге барлыкка килә, Мәскәүдә, Воронеж һәм Сембер губерналарында бодай оны, көнбагыш мае сатып алу б-н шөгыльләнгән Күмәртәле сатып алулар сәүдә җәмгыяте төзелә.

1917 дә Берлек Казан губерна кулланучылар җәмгыятьләре берлеге (Губсоюз) итеп үзгәртелә. Ел саен җәмгыятьләр саны 40 тан 820 гә, капитал 28,4 мең сумнан 252,4 мең сумга кадәр арта. Сугыш чоры шартлары товарлар кытлыгына китерә, сәүдә оешмаларын кредитлау начарая. 1918 дә Губсоюз составында 8,7 млн. сум еллык әйләнешле 1004

кулланучылар җәмгыяте исәпләнә. Шул ук елда Казан үзәк эшчеләр кооперативы барлыкка килә, аның составына яшәп килгән кооперативларның зур өлеше, 30 мең пайчы, 40 азык-төлек — «сыйнфый паёк» бүлүче, 120 мең кешегә хезмәт күрсәткән 9 икмәк заводы һәм 3 көнкүреш хезмәте күрсәтү остаханәсе керә. Шулай ук шәһәр халкының төрле катлаулары вәкилләрен берләштергән гомумгражданнар кооперативы эшли, аның 35 бүлү урынлы 30 бүлекчәсе була, кооператив 65 мең гражданны икмәк һ.б. продуктлар б-н тәэмин итә. 1919 да бу кооперативлар, Казанда 200 мең кешене колачлап, Бердәм кулланучылар җәмгыяте (БКҖ) составына керә. Эшчеләр кооперативлары Паратск Затоны, Кукмара авылларында, Тәтеш шәһәрендә һ.б. торак пунктларда эшли. Бер үк вакытта БКҖләр өязләрдәге волостьларда да оештырыла (Алабуга өязендә — 41, Казан өязендә — 22, Лаеш өязендә — 20, Мамадыш өязендә — 12, Зөя өязендә — 11, Спас өязендә — 17 һ.б.). 1918–20 дә волостьларда төрле товар кибетләре төзелә, алар товар алмашу б-н шөгыльләнә. Халык кытлык шартларында кулланучылар кооперативларына теләп керә, алар аша кирәкле товарларны сатып ала. 1930 еллар уртасына С.а.-к.к. үсеш алган сәүдә һәм җитештерү базалы эре хуҗалык оешмасына әверелә, сәүдәдә монополия били. 1941–45 тә фронт ихтыяҗларына эшли, җирле халык б-н берлектә фронт буе полосасыннан эвакуацияләнүчеләргә (226 мең кеше) сәүдә хезмәте күрсәтә. 1950–60 елларда кооператив сәүдә-җитештерү пр-тиеләре челтәре шактый үсә, сәүдә әйләнеше 2,6 млрд. сумга җитә. Шулай ук а.х. продуктлары һәм чимал әзерләүләр, аларны эшкәртү гамәлгә ашырыла, күп кенә халык куллануы товарлары җитештерелә. 1970 тә С.а.-к.к. системасына 800 мең пайчысы булган 210 кулланучылар кооперативын берләштергән 35 район кулланучылар берлеге керә; эшләүчеләр саны 29,7 мең кешегә җитә; авыл җирендә 1,7 млн. кешегә хезмәт күрсәтелә; сәүдә әйләнеше 543 млн. сум тәшкил итә. 1980 елларда С.а.-к.к. авыл җирендәге сәүдәдә монополия саклый. Аның 5 меңләп ваклап сату сәүдә пр-тиесе, 680 җәмәгать туклануы объекты була, 37 мең кеше эшли, 1,4 млн.га кадәр кеше яшәгән 3500 торак пунктка хезмәт күрсәтелә. 1980 дә, 1970 ел б-н чагыштырганда 67% ка артып, сәүдә әйләнеше 906 млн. сумга җитә (респ-ка күрсәткеченең 30% ы). Бу чорда оешмаларның җитештерү-техник базасын ныгыту буенча зур эш башкарыла.

1990 да ваклап сатуда С.а.-к.к. товар әйләнеше 1,4 млрд. сум тәшкил итә (1980 елга караганда 54,5% ка күбрәк). Күмәртәле сәүдә үсеш кичерә, аның әйләнеше 500 млн сумга җитә. 1990 елларның 1 нче яртысында С.а.-к.к. Белоруссия, Молдавия, Үзбәкстан, Украина, ш.у. Австрия, Италия, Иран, Кытай, Литва, Төркия, Шри-Ланка, Япония б-н сәүдә итә. 1993 тән Халыкара «Татреспотребсоюз» кооперация советын оештыручыларның берсе, 1994 тән Халыкара кооперация альянсы (1999 дан — РФ С.а.-к.к. Центросоюзының состав өлеше) әгъзасы була. Илдә һәм ТРда социаль-икътисади үзгәртеп корулар чорында С.а.-к.к. оешмалары эшчәнлегенең күрсәткечләре кискен түбәнәя. 1990 ел б-н чагыштырганда, 1995 тә сәүдә әйләнеше 67% ка кими, 942,8 млн. сум тәшкил итә. Шулай ук әзерләүләр, сәнәгать һәм азык-төлек товарлары җитештерү азая. 1990 елларның 2 нче яртысында — 2000 еллар башында базар мөнәсәбәтләренә күчү, катгый көндәшлек шартларында С.а.-к.к. пр-тиеләре эшчәнлеген тамырдан үзгәртеп кору таләп ителә. Азнакай, Алабуга, Арча, Әлки, Бөгелмә, Кукмара, Мамадыш һ.б. районнардагы кулланучылар җәмгыятьләре сәүдә әйләнеше үсешен тәэмин итәләр, оешмаларның матди-техник базасы яхшыра. Кибетләр челтәре — дискаунтерлар оештырыла, анда аз керемле халык өчен товарларның киң ассортименты булдырыла. Сатып алучыларны җәлеп итүнең төрле формалары һәм алымнары кулланыла: даими клиентларга ташламалар, китереп бирү һәм урнаштыруны кертеп, зур габаритлы товарларны (йорт җиһазлары, көнкүреш техникасы) кредитка сату, товарларны а.х. продукциясенә алмаштыру, өйдән заказлар кабул итү, иң кирәкле товарларга ташламалар, кибетләрне кеше күп йөри торган урыннарда төзү һ.б.

С.а.-к.к. өчен кадрларны Казан кооперация ин-ты, Россия сәүдә-икътисад ун-ты ин-ты (ф-лы), Казан кооперация техникумы һәм аның Бөгелмә ф-лы, 4 нче һөнәри лицей (Казан) әзерли.

*Әд.:* Шакиров Р. Кооперация мәңгелек // Татарстан. 1998. № 4; Низамиева Р. Хезмәт — кеше канаты, канатлы бул, канатлы... // Татарстан. 1998. № 8/9; Баязитов К.С., Шакиров Р.В. Больше века на службе людям (Из истории потребительской кооперации Республики Татарстан). К., 1995. *М.Җ.Гаитов, Е.П.Иванов.*

**САТЫ́Ш** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 9 *км* көньяктарак, Саба елгасы буенда. 2010 елда 679 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Борынча исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, баш-өс киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1865 тә төзелә), 3 су тегермәне, тимерчелек, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2264,3 дис. тәшкил итә. 1917 гә кадәр төбәктә иң зур уку йортларының берсе — җирле мәдрәсә (18 йөз ахырында ачыла) киң танылa. Ул махсус төзелгән таш бинага (19 йөз ахыры — 20 йөз башы архит-ра истәлеге) урнаша, анда 300 гә якын шәкерт (аны тәмамлаучылар арасында — шагыйрь М.Г.*Укмасый*, язучы М.В.*Гали*) белем ала. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Сатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 166 ир-ат; 1859 да — 1398, 1897 дә — 1656, 1908 дә — 1945, 1920 дә — 1734, 1926 да — 1540, 1938 дә — 1248, 1949 да — 983, 1970 тә — 928, 1979 да — 1282, 1989 да — 679, 2002 дә — 692 кеше.

**«САУЛЫ́К»**, карабодай сорты. 1995 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында Ф.З.*Кадыйрова*, Н.Н.*Петелина*, В.М.Галактионова, Л.С.Нижегородцева, И.Ю.Никифирова һәм А.Н.Бурмистров (Умартачылык фәнни-тикшеренү ин-ты) б-н бергә чыгарыла. Уртача өлгерешле; корылыкка һәм сөрлегүгә чыдам. 1000 орлыкның авырлыгы 35–36 *г*, тигезләнеше — 99,9%. Вегетация чоры 75–80 көн. Бер вакытта чәчәк ата. Иң югары уңыш — 1 *га* дан 41 *ц* 1993 елда Себер үсемлекчелек һәм селекция фәнни-тикшеренү ин-тында алына. Бөртегенең технол.һәм диетик үзлекләре югары. Дәүләт сынавы нәтиҗәләре буенча Россиянең барлык карабодай чәчү зонасында үстерергә рөхсәт бирелгән (1995–97). Татарстанда 2007 дә 9,8 мең *га* мәйданда үстерелә.

*Әд.:* Руководство по апробации сортовых посевов. К., 2002.

**САУРЫ́Ш** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Кече Чирмешән елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 20,5 *км*, бассейнының мәйданы 101,6 $км^2$. Идел аръягы түбәнлеге буйлап, Аксубай р-нында ага. Елга башы Заря посёлогы янында, тамагы Түбән Саурыш авылыннан 3,7 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 110 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. С.ның 1,3 тән 5,1 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,29 $км/км^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпеллык катламы 84 *мм*, ташу агымы катламы 82 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпеллык чыгымы 0,006 $м^3/с$. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада суының күләме 1,2 млн. $м^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**САУРЫ́Ш** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 23 *км* төньяк-көнбатыштарак, Саурыш елгасы буенда. 2010 елда 110 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 74%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рождественский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, тимерчелек һәм он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, Христово-Рождество чиркәве, земство (1871 дә ачыла), чиркәү-приход мәктәбе (1896) һәм ике сыйныфлы (1899) мәктәп, фельдшерлык пункты, тегермән, ярма яргыч, 3 тимерчелек, йөзем шәрабы базы, 2 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 3 вак-төякләр кибете була; сишәмбе базары һәм 2 ярминкә

(Пасхадан соң 9 нчы атнадан башлап якшәмбе көннәрендә һәм 10 сентябрьдә) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1310 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәм волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 160 ир-ат; 1859 да — 337, 1897 дә — 693, 1908 дә — 819, 1920 дә — 900, 1926 да — 798, 1938 дә — 630, 1949 да — 409, 1958 дә — 372, 1970 тә — 311, 1979 да — 342, 1989 да — 154, 2002 дә — 118 кеше.

**СА́УШКИН** Владимир Николаевич (1.1.1958, Әлмәт р-ны Югары Акташ а.), нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1991). Әлмәт нефть техникумын тәмамлый (1989). 1975 елдан «Татнефть» АҖнең «Әлмәтнефть» НГДУында: 3 нче, 6 нчы нефть промыселларында нефть һәм газ чыгару буенча мастер, оператор, НГДУның үзәк инженерлык-технол. хезмәтендә смена башлыгы. Дәүләт бүләге хезмәттә һәм фәнни-техник иҗаттагы алдынгы казанышлары өчен бирелә.

**САУЫ́Ш** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 13 *км* көньяктарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 421 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1680 нән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Кулар Савруш исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, ярма яргыч, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1404,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Ключище волостенда, 1920 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 85 ир-ат; 1859 да — 662, 1897 дә — 960, 1908 дә — 1160, 1920 дә — 1237, 1926 да — 1049, 1938 дә — 1077, 1949 да — 812, 1970 тә — 770, 1979 да — 679, 1989 да — 518, 2002 дә — 451 кеше.

**САФ КҮЛ**, Көнбатыш Кама алдында. Идел елгасының югары террасасында, Лаеш р-ны Травкино авылыннан 0,6 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Хәерби, Куян, Саламык күлләре б-н меридиаль юнәлештәге түбәнлектә урнашкан. Су өслегенең мәйданы 1,3 *га*. Су күләме 40 мең *м³*. Озынлыгы 170 *м*, иң зур киңлеге 90 *м*. Уртача тирәнлеге якынча 4 *м*, иң зур тирәнлеге 6,5 *м*. Озынча түгәрәк формада. Ярлары чагыштырмача текә, төньяктагы яры күтәренкерәк. Күл карст процесслары нәтиҗәсендә хасил булган. Туенуы күбесенчә җир асты сулары исәбенә, тотрыклы. Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта, җиңелчә минеральләшкән, йомшак, саргылт төстә. Үтә күренмәлелеге 40 *см*. Ял итү урыны. ТРның табигать истәлеге (1978).

**САФАГӘРӘ́Й ХАН** (1510 тирәсе, Бакчасарай ш. — 1549, Казан), Казан ханы (1524–31, 1535–46, 1546–49). Кырым тәхетендә утырырга омтылып 1524 елда Казаннан киткән *Сәхибгәрәй ханның* бертуганы Мөхәммәтгәрәй улы.


Мәскәү дәүләте Казан тәхетенә үзе билгеләгән кешене утыртырга тели. Шул максат б-н оештырылган рус гаскәре һөҗүме уңышсызлыкка дучар була, һәм тәхеткә *Булат Ширин* җитәкчелегендәге карачыбәкләр төркеме ярдәмендә С.х. утыра. 1526 да Мәскәү б-н солых килешүе төзелә, әмма 1530 да Рус хөкүмәте кабат сугыш башлый. Рус гаскәрләре Казанны камап алалар, әмма җиңеләләр. Хан хакимиятенең көчәюе Булат Ширин һәм Гәүһәршат ханбикә җитәкчелегендәге Казан аксөякләренең Кырымнан килүчеләргә каршы чуалышына китерә. Баш күтәрүчеләр, ярдәм сорап, Мәскәүгә мөрәҗәгать итәләр. 1531 нең маенда С.х. тәхеттән куыла, Нугай Урдасына, соңрак Кырымга кача; 1533 тә Кырым гаскәрләре ярдәмендә Рязань җирләренә басып керә. Казанның яңа ханы *Җангали* сәясәте аксөякләрдә канәгатьсезлек уята, һәм ул тәхеттән куыла. Казан тәхетенә кабат С.х. утыра. Ул *Сөембикәгә* өйләнә. 1536–37 дә, Мәскәүдәге үзара сугышлардан файдаланып, Рус дәүләтенә яу оештыра. С.х. гаскәрләре Түбән Новгород, Балахна, Муром шәһәрләрен камап ала. Канәгатьсез бәк-морзалар кабат Мәскәү б-н сөйләшүләр алып баралар. 1545 тә рус гаскәрләре фетнәчеләргә ярдәмгә киләләр, әмма уңышсызлыкка дучар булалар; Булат Ширин, Гәүһәршат һ.б. үтерелә. 1546 да С.х. Нарыйк улы Чура бәк, Боерган сәед һәм Кадыш бәк тарафыннан тәхеттән куыла. С.х. Нугай Урдасына, соңыннан Әстерханга кача. 1546 ның язында, Әстерхан ханы Ак Күбек б-н килешеп, Казанны камап алмакчы була. 1546 ның июль аенда, Нугай Урдасы бәге *Йосыф* б-н килешү төзеп, аннан гаскәр алып, Казанга кире кайта һәм *Шаһгалине* тәхеттән бәреп төшерә. Хакимиятне кайтаргач, С.х. Чура *Нарыйковны*, Кадыш бәкне һәм үзенең башка дошманнарын үтертә. 1549 ның мартында С.х. кинәт вафат була, тәхет аның улы *Үтәмешгәрәйгә* күчә.

*Әд.:* Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Алишев С.Х. Москва и Казань: межгосударственные отношения в XV–XVI вв. К., 1995; Трепавлов В.В. История Ногайской Орды. М., 2001; Исхаков Д.М., Измайлов И.Л. Введение в историю Казанского ханства. К., 2005.

*И.Л.Измайлов.*

**САФАКУ́Л РАЙОНЫ́**, *Курган өлкәсенең* көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1924 елда оештырыла. Мәйданы — 2280 *км²*. Үзәге — Сафакүл авылы (Курганнан 210 *км* көнбатыштарак). Халкы — 11673 кеше (2013). Татарлар саны: 1989 да — 6259, 2002 дә — 5641, 2010 да — 4398 кеше. Районда 4 татар торак пункты: Карасу, Мансур, Сөлекле, Бахарево бар; Аджитарово, Боровичи һәм Сафакүл авылларында татарлар башка милләт вәкилләре б-н бергәләп яшиләр. 17 йөздә С.р. терр-ясендә, башлыча, татарлар һәм башкортлар яши. Татарларның бу төбәкләргә күченүләренә, нигездә, яшәү урыннарындагы милли һәм дини изүләр сәбәп була. С.р.нда иң борынгы татар авылларының берсе — Сафакүл, аңа 1782 дә татар Сафа Юмагулов нигез сала. Сөлекле мәдәният йорты каршында татар театры (1989 дан халык исемен йөртә) һәм «Яшьлек» вокаль-инструменталь ансамбле эшли. Районда *Сабан туе*, «Каз туе», «Карга туе», «Кәккүк сәе» бәйрәмнәре даими уздырыла. Сафакүлдә 2001 дә татар һәм башкорт өлкә мәдәният үзәге ачыла, 2008 дә «Көньяк Урал һәм Урал аръягы татарларының рухи мирасы» фәнни-гамәли конференциясе үткәрелә. 2009 ның сентябрендә Сөлекле авылында «Җидегән чишмә» традицион татар халык мәдәнияте районара фестивале уздырыла. 2000/01 уку елында С.р.ның 4 мәктәбендә татар теле фән буларак өйрәнелә. Төрле культура һәм төрле халыклар яшәгән мохит шартларында Карасу урта мәктәбенә 2008 дә милли (татар) мәктәп статусы бирелә. С.р.нда Татарстан иҗат коллективлары һәм проф. артистлар гастрольләре даими үткәрелә. Курган өлкәсе б-н ТР арасында хезмәттәшлек турында килешү нигезендә С.р. һәм Татарстанның Яшел Үзән р-ннары арасында гуманитар хезмәттәшлек турында килешүгә кул куела һәм уңышлы гына тормышка ашырыла. 2011 дә Сафакүлдә Урал аръягы татарларының 3 нче корылтае уздырыла. С.р. спортчылары ТРга милли көрәш ярышларында катнашу өчен даими киләләр.

*Әд.:* Игризов С.Г. Страницы истории Сафакулевского района. Курган, 2000; Юсупов Ф.Ю. Сафакулевские татары: История, язык, фольклор. К., 2006.



В.С. Сафин.


**СА́ФИН** Вафа Сафа улы (23.10.1919, Зөя өязе Тугай а. — 6.11.2003, Яшел Үзән ш.), слесарь-ремонтлаучы, Соц. Хезмәт Герое (1971). ФЗУ тәмамлаганнан соң (1934), Яшел Үзән А.М.Горький исем. слесарьлык-ремонтлау з-дында эшли. 1938–80 елларда «Серго исем. завод» ҖБдә слесарь-ремонтлаучы, мастер (Яшел Үзән ш.). Герой исеме 8 нче бишьеллык планны (1966–70) үтәгәндә ирешкән уңышлары өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.


**СА́ФИН** Габделфәт Габдрахман улы (11.10.1962, Арча р-ны Симетбаш а.), эстрада җырчысы, ТРның халык артисты (2009). 1987 елда Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый, Казанның төзелеш оешмаларында эшли. 1992 дән Татар филармониясе солисты, 1994 тән «Моң» исемле шәхси студия-



Г.Г.Сафин.



Г.С.Сафин.



Д.А.Сафин.



З.З.Сафин.

сен җитәкли. Казан, Уфа, Татарстан һәм Башкортстанның башка шәһәрләрендә, ш.у. ТР-дан читтә татарлар тупланып яшәгән җирләрдә концертлар б-н чыгышлар ясый. Репертуарында — 200 дән артык җыр, башлыча, хәзерге татар композиторларының әсәрләре; 20 альбом яздыра. 2007 дән шәхси «Акчарлак» нәшрият йортын җитәкли, «Акчарлак» г-тасын нәшер итә. «Татар җыры» конкурслары лауреаты (2000–04).

Ә с ә р.: Язмышны һәркем үзе яза (әдәби-документаль җыентык). К., 1998.

**СА́ФИН** Галимҗан Мөбарәкҗан улы (1.9.1948, Әлки р-ны Түбән Салман а.), уролог, ТРның һәм РФнең атказ. табибе (1994, 2004). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), Респ-ка клиник хастаханәсенең (РКБ) 1 нче хирургия бүлегендә, 1978–81 елларда Казан шәһәренең 17 нче хастаханә поликлиникасында эшли. 1981 дән Казан ГИДУВының урология кафедрасында. 1983–88 дә РКБда. 1988 дән Казан шәһәре 7 нче клиник хастаханәсенең 1 нче хирургия бүлегендә, 1991 дән баш табиб, 2008 дән баш табиб урынбасары. Хезмәтләре бөер ташы авыруын дәвалауга карый. О.С.Кочнев һ.б. б-н берлектә бөер чәнчүне бастыру һәм сидек юлларыннан конкрементларны кудыру алымын тәкъдим итә. Уйлап табуга патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә, сәламәтлек саклау отличнигы (2006).

Х е з м.: Флебография при варикоцеле // Казан. мед. журн. 1988. № 3 (автордаш); Способ купирования почечной колики с одновременной регионарной стимуляцией мочеточников для изгнания конкрементов // Казан. мед. журн. 1991. № 6 (автордаш).

**СА́ФИН** Гәрәй Сафа улы (21.12.1907, Сембер губ., Буа өязе Атабай-Әнкәбә а. — 18.7.1975, Буа ш.), механик, Соц. Хезмәт Герое (1948). Бөгелмә а.х.н механикалаштыру мәктәбенең тракторист-машинистлар курсын тәмамлаганнан соң (1936), трактор бригадасы бригадиры, өлкән механик (1967 кадәр); бер үк вакытта трактористлар әзерләү курсларында укыта. С. җитәкчелегендә МТС-та техника ремонтлауда бригадаларда узеллап эшләү алымы кертелә. Герой исеме хезмәт күрсәтелгән к-зларда уҗым арышыннан югары уңыш алганы өчен бирелә (1947 — 1 *га* дан 21,2 *ц*, 626 *га* мәйданда). Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Буа шәһәрендә бер урам С. исеме б-н атала.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**СА́ФИН** Дамир Хәсән улы (19.8.1960, Балык Бистәсе р-ны Чаллыбаш а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (2006). 1982 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1985 тән «Түбәнкаманефтехим» АҖдә, этилен оксидын тикшерү лаб-ясе башлыгы (1988 дән), фәнни-технол. үзәк директоры урынбасары (1997 дән). С. этилен оксидлары һәм пропилен эшкәртүнең яңа технологияләрен, ш. и. моноэтиленгликоль, суыткыч һәм гидротормоз сыекчалары, пропиленгликоль һәм три-, тетраэтиленгликольләрнең экологик чиста метил эфирларын, нефть һәм газ сәнәгате өчен гади эфирларның яңа ассортиментын табу процессларын эшләүдә; пропилен, этилен оксидлары нигезендә этилен, моноэтиленгликоль, этилцеллозольв һәм этилкарбитол, гади полиэфир оксидлары алу технологияләрен камилләштерүдә һәм әлеге процессларның экологик проблемаларын хәл итүдә катнаша. Уйлап табуга 55 патенты бар (20 се җитештерүгә кертелгән). Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Некоторые особенности процессов получения статистических сополимеров окисей алкиленов // Хим. пром-сть сегодня. 2005. № 3 (автордаш); Сравнительные кинетические характеристики реакций взаимодействия спиртов с оксидами пропилена и этилена // Хим. пром-сть сегодня. 2005. № 8 (автордаш); Строение и молекулярные характеристики полиэфирных блоксополимеров на основе оксидов пропилена и этилена по данным спектроскопии ЯМР // Высокомолекулярные соединения. 2006. Т. 48, № 3 (автордаш).

**СА́ФИН** Дмитрий Анатольевич (8.12.1972, Кемерево өлкәсенең Междуреченск ш.), РФ Герое (4.5.2011), подполковник. Уссурийск суворовчылар хәрби уч-щесен (1989), М.В.Фрунзе исем. Киев югары гомумгаскәри уч-щесен (1992), Одесса коры җир гаскәрләре ин-тын (1993), РФ Кораллы көчләре гомумгаскәри академиясен (Мәскәү, 2004) тәмамлый. 1989 елдан СССР Кораллы көчләрендә. Себер хәрби округында хезмәт итә, РФ Кораллы көчләре Генштабының Баш разведка идарәсенең махсус 67 нче аерым бригадасы офицеры. 1995–2001 елларда беренче (1994–96) һәм икенче (1999–2009) Чечен кампанияләре вакытында 5 тапкыр командировкада була. 2000 нең апрель–май айларында Төньяк Кавказ төбәгендәге законсыз оешкан кораллы төркемнәрне юк иткәндә үткәрелгән террорчылыкка каршы операция вакытында батырлык күрсәтә. Мәскәүдә яши, РФ Кораллы көчләрендә хезмәтен дәвам итә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**СА́ФИН** Җәүдәт Фәйзрахман улы (31.1.1956, Питрәч р-ны Шәле а.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (2006), проф. (2007). 1978 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, 1979 дан шунда ук гражданлык хокукы һәм процессы кафедрасында эшли, 1990–98 дә юридик ф-т деканы урынбасары, 1998–2005 тә – гражданлык хокукы һәм процессы каф., 2005 тән экология, хезмәт хокукы һәм гражданлык процессы каф. мөдире. Хезмәтләре гражданлык, эшмәкәрлек, экология, җир хокукларын өйрәнүгә, хуҗалык итүче агросәнәгать комплексы субъектлары катнашында валюта-финанс хокукый мөнәсәбәтләрен җайлау мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Валютно-финансовые отношения с участием хозяйствующих субъектов агропромышленного комплекса. К., 2002; Особенности предпринимательских отношений с участием субъектов агропромышленного комплекса в валютно-финансовой сфере. СПб., 2005.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**СА́ФИН** Закир Вафа улы (26.2.1905, Казан губ., Чистай өязе Яңа Әлмәт а. — 6.3.1965, Казан), драма актёры, режиссёр, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1952). 1929 елда Казан театр-сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлый һәм Мәскәү үзәк татар эшче театры труппасына керә. Алдагы сезонда Әстерхан татар театрында эшли, анда ул К.Шамил җитәкчелегендә Булат, Ильяс («Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе», К.Тинчурин), Батырҗан («Наёмщик», Т.Гыйззәт), Муса («Хөсәен мирза», Ф.Бурнаш) рольләрен әзерли һәм башкара. 1932–34 тә Казан, Чистай, Әстерхан татар театрларында эшли. 1934 тә Мәскәүдәге Татар опера студиясенә укырга керә, аны тәмамлаганнан соң, Татар опера һәм балет театры актёры һәм режиссёры була. Режиссёр-репетитор булarак, 1939–49 да опера спектакльләре куюда катнаша, Н.Җиһановның «Илдар» операсын (В.М.Бебутов б-н берлектә), У.Хаҗибәковның «Аршин мал алан» муз. комедиясен куя. Н.Җиһановның «Ирек» операсы либреттосының һ.б.ның авторы. 1953 тә Татар акад. театры труппасына күчә, анда шактый гына характерлы рольләр башкара: Морат («Рәйхан», Н.Исәнбәт), Йосыпов («Минем хатын», М.Әмир), Гарвасий («Мартын Боруля», И.К.Карпенко-Карый), Миллер («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), Кент («Король Лир», У.Шекспир). 1961 дән Татар филармониясенең баш режиссёры.

*Әд.:* И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; Татарский академический театр оперы и балета им. М.Джалиля. К., 1994.

*И.И.Илялова.*

**СА́ФИН** Зәкәрия Зөфәр улы (26.8.1930, Әлмәт р-ны Югары Мактама а. — 8.8.1994, Казан), инженер-механик, «С.М.Киров исем. синтетик каучук заводы» ФҖБ ген. директоры (1987–94), Соц. Хезмәт Герое (1986). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1954). 1954–94 елларда «С.М.Киров исем. ясалма каучук заводы» ФҖБдә: мастер, цех башлыгы урынбасары, башлыгы, Казан ясалма каучук з-ды директоры (1965–87); 1962–65 тә партком секретаре. С. яңа махсус ясалма ка-

учуклар һ.б. полимер материаллар эшләүдә уникаль производстволар булдыруга өлеш кертә. Аның җитәкчелегендә техник яктан яңартып кораллану хисабына (өстәмә капитал салудан башка) кызуга чыдам силикон кремний-органик каучуклар җитештерү куәте проектта каралганнан 4, шул каучуклар нигезендә силикон резина катнашмалар эшләү куәте 3 тапкыр арттырыла. 1976–85 тә 50 дән артык яңа технологияләр гамәлгә кертелә, 46 төр (ш.и. 35 төр тармакта беренче буларак) продукция чыгару үзләштерелә; ял базасы, балалар учреждениеләре, санаторий-профилакторий, стационар поликлиника, Мәдәният йорты, Көнкүреш хезмәте күрсәтү йорты, 80 мең $м^2$ дан артыграк мәйданда торак йортлар төзелә. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы бар. Герой исеме 11 нче бишьеллык (1981–85) йөкләмәләрен вакытыннан алда үтәү, җитештерүне үстерүгә һәм камилләштерүгә керткән зур шәхси өлеше өчен бирелә. Ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумы Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. ФҖБнең адм. бинасына мемориаль такта (1999), Әлмәт шәһәренең Геройлар аллеясында С.ның бюсты (2005) урнаштырыла.

*Әд.:* Зрелость: Страницы истории Казанского завода синтетического каучука им. С.М.Кирова. К., 1986; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003. *Г.Я.Мәүлетова.*

**СА́ФИН** Ибраһим Афзал улы (4.9.1927, Пермь ш. — 31.12.1997, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1981), ТР ФА мөхбир әгъзасы (1992). 1950 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, «Радиоприбор» з-дында эшли (Казан). 1954 тән РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында, төш магнетизмы лаб-ясе мөдире (1973–89), баш фәнни хезмәткәр (1989 дан). Хезмәтләре каты җисемне ТКР (төш квадруполь резонансы) алымы б-н тикшерүгә карый. С. электроакустик кайтаваз күренешен ача (бергәләп, 1970). ТКР күренешен теркәү һәм тикшерү өчен спинлы кайтаваз режимында импульслы ысуллар уйлап таба һәм куллана. Минерал. һәм азотлы кушылмалар физик химиянең төрле мәсьәләләрен, каты җисемнәр физикасының башка проблемаларын өйрәнү өчен ТКР алымы куллануның яңа юнәлешләрен үстерә (бергәләп). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Измерение времён ядерной квадрупольной релаксации // Приборы и техника эксперимента. 1962. № 3; Таблицы частот ядерного квадрупольного резонанса. Л., 1968 (автордаш); Ядерный квадрупольный резонанс в соединениях азота. М., 1977 (автордаш); Особенности спектров ЯКР $^{63,65}Cu$ хлорированной керамики $YBa_2Cu_3O_x$ // Сверхпроводимость: Физика, химия, техника. 1995. Т. 8, № 3 (автордаш).

**СА́ФИН** Ибраһим Кәрим улы (13.11.1919, Казан губ. Чистай өязе, хәзер Нурлат р-ны Урта Чаллы а. — 23.1.2006, шунда ук), генерал-майор (1970). Л.Б.Красин исем. Мәскәү 1 нче артиллерия уч-щесен (1941), Ф.Э.Дзержинский исем. артиллерия академиясен (Мәскәү, 1951) тәмамлый. 1939 елда «Октябрь колхозчысы» (Нурлат штп) район г-тасы сәркәтибе. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында: 685 нче корпус һәм 528 нче артиллерия полкларының артиллерия батареясы командиры. Мәскәү (1941–42), Львов-Сандомир (1944)) һәм Прага (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1945–48 дә Австрия, Украина, Төркестан хәрби округларында совет гаскәрләре составында хезмәт итә. 1951–70 тә Балтыйк буе хәрби округында сугышчан әзерлек бүлеге башлыгы, ракета корпусы штабы башлыгы. 1970–73 тә Ф.Э.Дзержинский исем. артиллерия академиясендә, 1974–81 дә СССР Мелиорация һәм су хуҗалыгы министрлыгының су ресурсларын саклау бүлегендә эшли. 1986–99 да Одесса шәһәренең Үзәк р-ны ветераннары советы рәисе. 1999 дан туган авылында яши. 3 нче дәрәҗә Богдан Хмельницкий, Александр Невский, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Ике Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Кызыл Мәйдандагы Җиңү Парадында 8 тапкыр катнаша.

*Әд.:* Гордость земли Нурлатской. Кн. 1: Вспомним годы фронтовые. Самара, 2005.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СА́ФИН** Илсур Кәрип улы (11.8.1962, Апас р-ны Югары Балтай а.), җырчы, педагог, ТР-ның халык артисты (2008). 1989 елда Казан консерваториясен (Ә.Заһидуллина классы) тәмамлый. 1989–98 дә Татар филармониясе солисты. 2001 дән мөстәкыйль концерт эшчәнлеге алып бара, бер үк вакытта, 2005 тән, Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында укыта. Репертуарында — хәзерге татар композиторларының җырлары (ш.и. И.Закировның Ш.Җиһангирова сүзләренә язылган «Сөюем бакчасы», И.Мәҗитовның Г.Зәйнашева сүзләренә язылган «Казан — минем язмышым», Л.Хәйретдинованың Г.Рәхим сүзләренә язылган «Янма син, йөрәк!»), татар классик эстрада музыкасы (С.Сәйдәшев, А.Ключарёв, Р.Яхин һ.б.ның әсәрләре), халык җырлары, рус романслары. С.Сәйдәшев исем. 1 нче респ-ка конкурсы (1990), халыкара «Татар җыры — 1993» конкурсы лауреаты.

**СА́ФИН** Ильяс Дилшат улы (29.1.1967, Азнакай штп), РФ Герое (27.12.2009), гв. өлкән сержанты. 1991 елда И.М.Губкин исем. Мәскәү нефть һәм газ ин-тын тәмамлый. 1985 нең апреленнән Совет Армиясе сафларында. Төркестан хәрби округындагы гаскәри разведканың Термез уку-укыту үзәгендә әзерлек үтә. 1985 нең 1 августыннан Әфганстан Демократик Респ-касындагы сугыш хәрәкәтләрендә өлкән разведчик, 201 нче Гатчина мотоукчы дивизиясенең Ченстохов полкында 149 нчы гв. мотоукчы разведка ротасының кузәтү взводы командиры урынбасары. 1985 нең 16 октябрендә Андараб үзәне Баглан провинциясенең көньягындагы операциядә полк командирының дошман штабының яшерен документларын кулга төшерү заданиесен үтәгәндә батырлык күрсәтә: С. тәрҗемәче А.Х.Холтураев б-н бергә ут астында кала; сугыш кырыннан яралы иптәшен алып чыга; өстәмә көчләр килгәнче сугышны дәвам итә. Сугыш барышында дошманның ике ут ноктасын юк итә. 1986 ның 22–23 августында Кокари-Шаршари (Герат провинциясе) р-ны



Илсур К. Сафин.



И.Д. Сафин.

ныгытмасын штурмлаганда батырлык күрсәтә: гомерен куркыныч астына куеп, дошманның ут ноктасын юк итә. Сугышта каты яралана. 1993–95 тә Әфганстан ветераннары берлеге рәисе урынбасары, бер үк вакытта, 1994–95 тә, Россиянең Әфган сугышы инвалидлары фонды рәисенең 1 нче урынбасары (Мәскәү). Ветераннар оешмасы эшләрен координацияли һәм Әфган сугышы ветераннарын һәм инвалидларын социаль-көнкүреш, хокукый һәм мед.-психол. тернәкләндерү мәсьәләләре буенча берләштерелгән эксперт советы б-н җитәкчелек итә. Мәскәү Хәрби хезмәт инвалидларын социаль яклау фондын оештыручы һәм башкарма директоры (1996 дан). БДБ илләре хөкүмәт башлыклары Советы каршындагы сугышчы-интернационалистлар эшләре ком-ты киңәшчесе (2006). Ике Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.


*Әд.:* Л а т ы п о в Т. Наш земляк — Герой России // Время и деньги. 2010. 13 янв.

**СА́ФИН** Ирек Әхмәт улы (15.6.1932, Әлмәт р-ны Мәмәт а. — 23.1.2004, Уфа ш.), хирург, мед. фән. д-ры (1985), проф. (1986), Башкортстан Респ-касының атказ. табибе, атказ. фән эшлеклесе (1993, 1999). Башкорт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1957), Башкортстанның Мишкә район хастаханәсендә хирург һәм баш табиб булып эшли. 1961 елдан Башкорт мед. ин-тының — хирургия, 1971 дән гомуми һәм факультет хирургиясе кафедрасында. Бер үк вакытта, 1963–65 тә, Респ-ка клиник хастаханәсендә (Уфа) хирургия бүлеге мөдире. 1965–68 дә Халыкара Кызыл Хач җәмгыяте госпиталендә эшли (Сомали Респ-касы). Фәнни тикшеренүләре хроник гепатит һәм бавыр циррозын, үт юлларын хирургик дәвалау өлкәсенә карый. С. бавырның хроник зарарлануы очрагы өчен артериализация методикасын эшли, беренче булып биол. актив пластик материал сыйфатында «Аллоплант» регенерация стимуляторын куллана. Ашказаны һәм уникеилле эчәк ялкынсынуын, остеомиелитлар, трофик җәрәхәтләрне, үлекле һәм үлексез яраларны, бавырның диффуз һәм аерым авыруларын һ.б. түбән һәм югары энергияле лазер кулланып хирургик дәвалау алымнарын эшли һәм гамәлгә кертә. Уйлап табуга 3 патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә. Респ-ка клиник хастаханәсенең хирургия корпусына (Уфа) мемориаль такта куела.

Х е з м.: Итоги и перспективы развития хирургии печени и желчных путей // Здравоохранение Башкортостана. 2004. № 1 (автордаш); Лазерное излу-



Нәкыйп С.Сафин.



Н.В.Сафин.

чение в сочетании с аллогенным материалом в лечении ран // Здравоохранение Башкортостана. 2004. № 3 (автордаш); Возможности использования лазерного излучения при оперативном лечении эхинококкоза // Здравоохранение Башкортостана. 2005. № 1 (автордаш).

**СА́ФИН** Камил Мостафа улы (17.6.1937, Алексеев р-ны Юеш Көрнәле а. – 28.11.2016, шунда ук), техник-механик, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. а.х. хезмәткәре (1987). Чистай а.х. техникумын тәмамлый (1970). 1967–2008 елларда Алексеев р-нының «Родина» к-зында эшли: бригадир (1967 дән), партком секретаре (1970 тән), рәис (1972–2003). С. җитәкче булганда, 1,5 мең баш мөгезле эре терлек өчен бина, 125 фатир, урта мәктәп, 2 клуб, бөртекле ашлыкны сортларга аеру буенча 3 линия төзелә; Юеш Көрнәле, Бутлеровка авылларына газ кертелә; юлларга асфальт салына. 1972–2002 дә ит җитештерү 97,1% ка, сөт — 128,5% ка, бөртекле ашлык 125,1% ка арта. 2003 тә бөртеклеләрнең уңышы 1 *га* дан 60,3 *ц* га, еллык савым һәр сыердан уртача 6141 *кг* га җитә. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

**СА́ФИН** Ленар Ринат улы (11.2.1969, Арча ш.), хокук белгече, хакимият-эшлеклесе, юридик фән. канд. (2004). Казан ун-тын (1993), Казан финанс-икътисад ин-тын (2000) тәмамлый. 1993–95 елларда Казан финанс-икътисад ин-тының тарих һәм хокук кафедрасында, 1995–2008 дә Казан ун-тының җинаять хокукы һәм криминология кафедрасында. 2008–09 да «Главтатдортранс» баш идарәсе директоры урынбасары, 2009–10 да директоры. 2010 нан ТР транспорт һәм юл хуҗалыгы министры. Җинаять хокукы, хөкем ителгән затларның җәмгыятьтән аеру б-н бәйле булмаган җәзаларны узудан явыз ният белән читләшүе мәсьәләләре буенча хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Ответственность осуждённых за злостное уклонение от наказаний, не связанных с изоляцией от общества в российском уголовном праве. К., 2009.

**СА́ФИН** Мансур Габдулла улы (11.5.1949, Кемерово өлкәсенең Анжеро-Судженск ш.), язучы, тәрҗемәче. Татар һәм рус телләрендә яза. Оренбург зенит-артиллерия уч-щесен (1969), Казан ун-тын (1975), Чаллы патент ин-тын (1992) тәмамлый. 1978 елдан Чаллыда яши: КамАЗда эшли, 1995 тән «Аргамак» ж-лының баш мөхәррире урынбасары, 1999 дан Чаллы пед. ин-тында укытучы, 2001 дән «Бизнес-класс» ж-лының баш мөхәррире урынбасары, 2007 дән Үзәк китапханәләр системасы методисты. «Мамадыш таңнары» (1992), «Хәерле иртә» (Чаллы, 1994), «Өмет, Ышаныч һәм Мәхәббәт» («Вера, Надежда и Любовь», Чаллы, 1994), «Мамадышка мәдхия» («Ода Мамадышу», Чаллы, 2007) шигырь җыентыклары, балалар өчен «Сербакчага сәяхәт» (1997), «Сыерчык бураны» (2004) җыентыклары, туган якны өйрәнүгә багышланган «Мамадыш — былиналар төбәге» («Край былинный, Мамадышский», 1994), «Гомер хакына — утка» («В огонь — во имя жизни», 1998), «Чаллыны өйрәнү» («Челноведение», 2006) китаплары авторы. Рус теленә Э.Касыймов, М.Насыйбуллин, Е.Уткин, Ф.Бәйрәмова, З.Гомәрова, Г.Асанов, В.Казыйханов әсәрләрен, татар теленә М.Цветаева, Б.Пастернак, Н.Рубцов, В.Высоцкий әсәрләрен тәрҗемә итә.

*Әд.:* П р и х о ж а н П. Пространство ожидания Добра // Аргамак. 1999. № 5; Ч у п р и н и н С. Новая Россия: мир литературы: Энцикл. словарь-справ. М., 2003. Т. 2. *Б.А.Канеев.*

**СА́ФИН** Марат Габдрахман улы (3.3.1935, Югары Ослан р-ны Татар Макылы а.), эпизоотолог, вет. фән. д-ры (1981), проф. (1982), ТАССР һәм РСФСРның атказ. вет. табибе (1973, 1985), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2002). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), Чаллы р-ның «Татарстан» с-зында баш вет. табибе булып эшли. 1963 тән Казан вет. ин-тында (1995 тән Казан. вет. медицинасы академиясе): эпизоотология каф. мөдире (1980–2005), каф. профессоры (2005–10), бер үк вакытта проректор (1988–95). Туберкулёз, бруцеллёз һәм хайваннардагы башка йогышлы авыруларга диагноз кую, авыруларны кисәтү һәм дәвалау ысулларын эшли һәм фәнни нигезли. Уйлап табуга патенты бар. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1996). «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Туберкулёз крупного рогатого скота. М., 1985 (автордаш); Туберкулёз сельскохозяйственных животных и меры его профилактики. К., 1990 (автордаш); Болезни животных, передающиеся от животных к человеку. К., 1994 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.


**СА́ФИН** Марат Мөбин улы (27.1.1980, Мәскәү), спортчы (теннис), Россиянең атказ. спорт остасы. Спорт б-н 1990 елда Цинциннати шәһәренең (АКШ) Теннис академиясендә шөгыльләнә башлый. 1994–98 дә Валенсия шәһәренең Панчо Альварино Теннис академиясендә (Испания). Тренерлары — Р.Менсуа (1994–98), А.Чесноков, А.Волков, Т.Пиккард (2000), М.Уиллард (2001), Д.Голованов (2002), П.Лундгрен (2004–05), Э.Гуми (2007) һ.б. «Челленджерс» (1998), «Зур шлем» — «US Open» (2000, АКШ; 2005, Австралия), «Masters» (2000, 2002, 2004) серияләрендә; АКШның ачык чемпионаты (2002) турнирларында җиңүче. Дөньяның беренче ракеткасы (2000), Дэвис Кубогы (2002, 2006, Россия милли командасы составында), Кремль Кубогы (2007, парлы разрядта) иясе. «Елның иң яхшы яңа спортчысы» теннисчы-профессионаллар ассоциациясе призы лауреаты (2000), «US Open» рейтингында 1 нче урында. «Рус Кубогы» бүләге иясе (1998, 2004). 1996 дан Россия җыелма командасында, 1997–2009 дан проф. теннисчы. РФ Дәүләт Думасы депутаты (2011 дән). Почёт, Дуслык орденнары б-н бүләкләнә. Монте-Карло (Монако) шәһәрендә яши.

**СА́ФИН** Мидхәт Ризван улы (25.6.1936, Балтач р-ны Хәсәншәех а.), спортчы, тренер (спорт гимнастикасы), СССРның спорт остасы (1961), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2005), ТАССРның атказ. физик культура хезмәткәре (1987), биол. фән. канд. (1976). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1956). Татарстан респ-ка советының «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (тренер — В.И.Коган). ТАССР чемпионы (1956–60), РСФСР Халыклары спартакиадаларында бронза медаль ала (1956). 1956 дан «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тренерлык һәм укыту эшендә; 1961 дән Казан химия-технол. ин-тында, 1963 тән Казан югары хәрби команда-инженерлык уч-щесендә, 1966 дан Казан югары спорт осталыгы мәктәбендә, 1970–73 тә Казан пед. ин-тында. 1973 тән Казан энергетика ун-тында, физик тәрбия каф. мөдире (1979–2002), проф. (1993 тән). Хезмәтләре физик күнегүләр, дәвалау һәм сәламәтләндерү гимнастикасы физиологиясенә карый.

**СА́ФИН** Нәкыйп Сафа улы (15.3.1921, Арча кантоны Мирҗәм а. — 22.5.1987, Казан), Сов. Союзы Герое (20.12.1943), майор. Хәрби инженерлар уч-щесен (1946), КПССның Татарстан өлкә ком-ты каршындагы Казан югары респ-ка партия мәктәбен (1951) тәмамлый. Туган авылында колхозда, Иркутск өлкәсендә тимер юлда эшли. 1940 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында; Дала фронты гаскәрләре составында 19 нчы аерым моторлаштырылган понтон-күпер батальонында отделение командиры. Солошино авылы (Полтава өлкәсенең Кобеляки р-ны) янында Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: 1943 нең 28 сентябрендә, дошман плацдармын кулга төшерү өчен, елганың уң ярына понтон б-н автоматчылар төркемен чыгара (18 рейс ясый), соңыннан паром б-н елга аша танклар һәм артиллерияне чыгара. 1946 дан запаста. 1956–64 тә Шушмабаш (Арча р-ны) авылында «Северный» с-зы директоры, 1964 тән Юдино посёлогында (Яшел Үзән р-ны) совхоз директоры. Ике Ленин ордены, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Казан шәһәрендә һәм Арча шәһәрендә С. исеме б-н урамнар атала. Мирҗәм авылында Геройга бюст куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000. *М.З.Хәбибуллин.*

**СА́ФИН** Нуриәхмәт Вәлиәхмәт улы (15.12.1946, Алексеев р-ны Кыр Шонталысы а.), драма актёры, ТРның халык артисты (1994), РФнең атказ. артисты (2007). 1966 елда — Казан театр уч-щесен, 1983 тә Башкорт ун-тының филол. ф-тын тәмамлый. 1966–68 дә Алексеев р-ны мәдәният йортларында методист булып эшли. 1968–86 да Татар респ-ка күчмә театры актёры, 1986–89 да



Н.В.Сафин 1. Лир («Король Лир», У.Шекспир); 2. Алпамша («Сак-Сок», Р.Батулла) рольләрендә.

«Тасма» ҖБнең мәдәният йорты директоры, 1989 дан ТАССР Мәгариф министрлыгы каршындагы студия, аннан соң Казан татар яшь тамашачылар театры актёры, соңгысын оештыруда актив катнаша. С. Татар респ-ка күчмә театрында Хизәятхан («Мәйсәрә хәйләләре», Х.Ниязи), Гомәр («Караком фаҗигасе», О.Бадыйков), Мәхмүт («Җәяүле Мәхмүт», М.Кәрим), Солтангәрәй, Мияссәр («Шикәрем син, балым син», «Ефәк баулы былбыл кош», А.Гыйләҗев), Дон Педро («Шау-шулы көн», У.Шекспир) рольләрен башкара. Көчле темпераментка, муз. сәләткә ия булу С.га Казан татар яшь тамашачылар театры сәхнәсендә Һади Такташ («Атылган йолдыз», Ф.Бәйрәмова), Хәмзин, Шакир («Сандугачлар килгән безгә», «Хуш, Хәйбуш!», И.Юзеев), Юлдаш («Оят төне», Б.Мукаев), Кәрим бай, Шәехзаман («Башмагым», «Кыю кызлар», Т.Гыйззәт), Йагъкуб («Йосыф-Зөләйха», Кол Гали поэмасы буенча), Президент фон Вальтер («Мәкер һәм мәхәббәт», Ф.Шиллер), Лир («Король Лир», У.Шекспир), Салих Сәйдәшев («Умырзая», Р.Харис) кебек зур образлар иҗат итәргә мөмкинлек тудыра. Д.Сираҗиев исем. театраль бүләк лауреаты (2011).

**СА́ФИН** Нурмөхәммәт Сәфәргали улы (1903, Казан губ., Лаеш өязе Апакай а. — 9.5.1945, Казан), җырчы. 1925 елдан башкару эшчәнлеге алып бара. 1928 дән Татар радиосында муз. редактор һәм солист, 1939–45 тә ТАССРның Җыр, бию һәм музыка ансамбле солисты. Җырчының репертуарын татар, башкорт һәм рус халык җырлары, татар, Европа һәм рус композиторларының җырлары һәм романслары (ш.и. татар теленә тәрҗемәдә) тәшкил итә.

Х е з м.: Татар музыкасы турында // Яңалиф. 1931. № 8–9; 11.

**СА́ФИН** Нурулла Дәүләтгәрәй улы (25.7.1923, хәзер БРның Аскын р-ны Иске Казанчы а. — 15.5.1995, шунда ук), Сов. Союзы Герое (10.4.1945), гв. өлкән сержанты. Туган авылында ат караучы, бригадир. 1943 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 тән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 467 нче гв. миномётчылар полкында миномётчылар расчёты командиры (3 нче гв. танк армиясенең 7 нче гв. танк корпусы). Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Житомир-Бердичев (1944), Львов-Сандомир (1944) һәм Сандомир-Силезия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Грошовиц авылы (Польша) янында Одер елгасын кичеп чыкканда батырлык күрсәтә: 1945 нең 23 гыйнварында С. беренчеләрдән булып елганы кичеп чыга, плацдармны киңәйтү сугышында катнаша; дошманның контрһөҗүмен кире кайтарып, бик күп сугышчыларын һәм техникасын зур югалтуларга дучар итә. 1946 да демобилизацияләнә. Сугыштан соң Азин исем. к-з рәисе урынбасары, «Дуслык» с-зының хуҗалык эшләре буенча директор урынбасары, Аскын р-нының Казанчы авыл советы рәисе булып эшли. Пенсиягә чыккач, Уфа шәһәренә күченә. Ленин ордены, ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Геройга Уфа шәһәрендә һәм Иске Казанчы авылында мемориаль такта урнаштырыла.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СА́ФИН** Радик Ильяс улы (13.2.1969, Лениногорск ш.), галим агроном, а.х. фән. д-ры (2003), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2008). 1990 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (хәзер — Казан аграр ун-ты), гомуми игенчелек, селекция һәм үсемлекләрне саклау каф. мөдире (2010 нан). Хезмәтләре үсемлекләрне саклау мәсьәләләренә карый. С. а.х. культуралары чәчүлекләренең фитосанитар мониторингы һәм туфрак-орлык инфекцияләрен күзәтү системасын эшли. ТР өчен бәрәңге, бөртекле культураларның яңа төр патогеннарын һәм аларны җайлаштыру механизмнарын ача. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Научные основы повышения продуктивности картофельных агроценозов. К., 2002; Заражённость семян различных сортов яровой пшеницы токсинообразующими грибами // Агро XXI. 2004/2005. № 7/12 (автордаш); Борьба с корневыми гнилями приносит успех // Защита растений и карантин. 2007. № 10 (автордаш).

**СА́ФИН** Рәдиф Сәләх улы (19.3.1951, Әтнә р-ны Олы Әшкәтә а.), тренер (чаңгы спорты), РСФСР, ТРның атказ. тренеры (1991, 1996), ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (2001). Әлмәт физик культура техникумын (1974), Волгоград физик культура ин-тының Чаллы ф-лын (1992) тәмамлый. 1972–74 елларда Казан «Органик синтез» з-дында аппаратчы. 1974–81 дә «Спартак» ирекле спорт җәмгыятенең Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә, 1981–98 дә Татарстан респ-ка советының «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә (Әлмәт ш.), 1999 дан — ТРның Физик культура, спорт һәм туризм (2005 тән — ТРның Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы) дәүләт ком-тының Үзәк спорт клубында тренер. Шәкертләре арасында РСФСР, СССР, дөнья беренчелекләрендә һәм чемпионатларында, Олимпия уеннарында берничә тапкыр җиңүчеләр — А.Власов, О.В.*Данилова*, В.Н.Крымцова бар.


Н.Д.Сафин.

**СА́ФИН** Рәис Сәмигулла улы (15.7.1950, Чуаш АССРның Батыр р-ны Татар Тимәше а.), педагог, агынты сулар һәм чистарту җайланмалары буенча белгеч, техник фән. канд. (1973), пед. фән. д-ры (1998), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2007). Ленинград төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый (1973). Казан архит-ра-төзелеш ун-тында эшли, әзерлек бүлеге мөдире (1985–90), инженерлык системалары һәм экология ф-ты деканы урынбасары (1990–95), деканы (1995 елдан), бер үк вакытта, 2007 дән, һөнәри белем бирү каф. мөдире. Казан һәм Татарстанның көнкүреш һәм сәнәгать пр-тиеләренең агынты суларын чистартуның яңа алымнарын һәм аппаратларын эшли. Хезмәтләре төзелеш белгечлекләре студентларын заманча укыту алымнарына карый. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Проектирование эргономических технологий обучения студентов инженерно-строительных специальностей. К., 2001.

**СА́ФИН** Ринат Ибраһим улы (29.7.1940, Яшел Үзән р-ны Олы Җәке а. – 22.10.2014, Ленинград өлкәсе), спортчы (чаңгы спорты-биатлон), СССРның атказ. спорт остасы (1969). Ленинград физик культура техникумын тәмамлый (1976). «Динамо» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Ленинград). СССР (1967, 1970–72), дөнья (1969–1971, 1973), Олимпия уеннары (1972, 4×7,5 *км* эстафетада узышу) чемпионы; дөнья чемпионатында көмеш медаль ала (1967, 4×7,5 *км* эстафетада узышу; 1969, 20 *км* га аерым узышу). «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**СА́ФИН** Руслан Рушан улы (26.2.1977, Казан), агач эшкәртү технологиясе өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2007). 1999 елда Казан. технол. ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 2000–07 дә агач эшкәртү кафедрасында, агач эшләнмәләр архит-расы һәм дизайны каф. мөдире (2008 дән). Хезмәтләре агач материалын киптерү һәм саклау өчен энергия саклаулы технологияләргә һәм җиһазларга карый. Агачны җылылык ярдәмендә эшкәртү, сеңдергечләр куллану һәм термомодификацияләү өлкәсендә тикшеренүләр үткәрә. С.ның материалларны вакуумлы-конвектив киптерү һәм агачны термомодификацияләү җайланмалары буенча хезмәтләре ТР һәм РФнең төрле пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән. Уйлап табуга 12 патенты бар.

Х е з м.: Новые подходы к совершенствованию вакуумно-конвективных технологий сушки древесины // Деревообрабатывающая пром-сть. 2005. № 5 (автордаш); Вакуумная сушка пиломатериалов при конвективном теплоподводе. К., 2006; Ма-

тематическая модель процесса конвективной сушки пиломатериалов в разреженной среде // Изв. вузов. Лесной журн. 2006. № 4 (автордаш).

**СА́ФИН** Рушан Гәрәй улы (14.8.1950, Казан), җитештерүне автоматлаштыру өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1992), проф. (1994), ТР һәм РФнең атказ. уйлап табучысы (1991, 1998). 1973 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1977 дән Казан технол. ун-тында, агач материаллары эшкәртү кафедрасын оештыра һәм аны җитәкли (1995 тән).

Хезмәтләре агач эшкәртүдәге җылылык һәм масса алмашу процессларына, энергия саклаулы калдыксыз технологияләргә һәм җиһазларга карый. С.ның фәнни тикшеренүләре сәнәгать ташландыкларын һәм агынты суларны чистарту; агачны бионефтькә әверелдерү; пиролиз, газ генерациясе һәм яну, вакуумлы киптерү, сеңдерү, термомодификацияләү, агачсыл үсемлекләрнең кабыгы һәм яшел массасыннан төрле матдәләр алу мәсьәләләренә багышлана. Аның җитәкчелегендә ТРның төрле пр-тиеләрендә азот оксидларыннан, күкерт к-тасы парларыннан һәм акролеиннан чистарту җайланмалары, киез җитештерүдә конвектив киптергечләр, агач эшкәртү һәм урман хуҗалыгы калдыкларыннан бионефть табу технологиясе; сулы пульпаны үзәккә туплау җайланмасы уйлап табыла һәм гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 114 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Технологические процессы и оборудование деревообрабатывающих производств: В 2 ч. М., 2002–03; Основы переработки древесных материалов. М., 2005; Ресурсо- и энергосберегающие технологии и аппаратурное оформление процессов, сопровождающихся выделением газовой фазы. К., 2008 (автордаш).

**СА́ФИН** Салих Гарифулла улы (16.3.1923, Спас кантоны Әҗмәр а.), профсоюз эшлеклесе. Куйбышев пед. уч-щесен (ТАССР, 1941), Казан югары партия мәктәбен (1961), Минзәлә а.х. техникумын (1964) тәмамлый. 1941 елда Бурят-Монгол АССРда авыл мәктәбендә укытучы. 1941–45 тә Кызыл Армиядә хезмәт итә. 1946–52 дә Куйбышев р-нының Әҗмәр авылында укытучы (бүленеп: 1947–48 дә ВЛКСМның Куйбышев район ком-ты 1 нче секретаре). 1952–57 дә КПССның Куйбышев район ком-тында инструктор, бүлек мөдире, секретарь булып эшли. 1961–62 дә Татарстан өлкә ком-ты инструкторы. 1962 дә КПССның Минзәлә район ком-ты 1 нче секретаре. 1962–65 тә Питрәч колхоз-совхоз җитештерү идарәсенең партия ком-ты секретаре. 1965–71 дә КПССның Актаныш район ком-ты 1 нче секретаре. 1972–84 тә Профсоюзларның Татарстан өлкә советы рәисе. 1963–85 тә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**СА́ФИН** Тәүфикъ Фәтхерахман улы (3.1.1938, Ульянов өлкәсенең Чынлы р-ны Яңа Тимерчән а.), хирург, сәламәтлек саклау өлкәсендә оештыручы, ТАССР һәм РФнең атказ. табибе (1991, 1995). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1968), Казан шәһәренең 1 нче клиник хастаханәсендә эшли. 1971–74 елларда Казан мед. ин-тының госпиталь хирургиясе кафедрасында. 1974–77 дә Казан шәһәре сәламәтлек саклау бүлеге мөдире урынбасары, 1977–82 дә Казан мед. ин-тында. 1982–85 тә ТАССР сәламәтлек саклау министры урынбасары. 1985–87 дә Казан шәһәре сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы, 1987 дән Казан шәһәре 12 нче клиник хастаханәсендә, 1989 дан баш табиб. Фәнни тикшеренүләре сәламәтлек саклау өлкәсе мәсьәләләренә, мәҗбүри мед. иминиятләштерүгә карый. ТР ЮС депутаты (1990–95). ТР Халык депутаты (1995–2000). ТР Дәүләт Советы депутаты (2000–09). «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**СА́ФИН** Тимергали Гыйлем улы (5.10.1924, хәзер Сарман р-ны Саклаубаш а. — 28.4.2010, шунда ук), агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. агрономы (1979). Колхоз рәисләре әзерләү буенча Татарстан а.х. мәктәбен (1955), Казан а.х. ин-тын (1966) тәмамлый. 1944–89 елларда Сарман р-нында эшли: «Уңыш» к-зы рәисе (1947 дән), «Нөркәй» с-зы бүлеге идарәчесе (1957 дән), «Комбайн» к-зы рәисе (1958 дән), «Нөркәй» с-зы агрономы (1963 тән), «Тукай» с-зы директоры (1965 тән). С. җитәкче булганда, «Тукай» с-зында идарә итүнең цех структурасы, хуҗалык исәп-хисабы гамәлгә кертелә, җитештерүдә 300 дән артык объект, социаль-мәдәният һәм көнкүреш биналары төзелә, бөртекле ашлык, сөт, ит, йон җитештерү арта. Табышлылык дәрәҗәсе 40–45% тәшкил итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Окт. Революциясе, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, Хезмәт Кызыл Байрагы, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. Саклаубашта бер урам С. исеме б-н атала.

**СА́ФИН** Фаил Габдулла улы (20.1.1959, БАССРның Дәүләкән р-ны Бик-Карамалы а.), этнолог, тарихчы, тарих фән. д-ры (2001). Башкорт ун-тын тәмамлый (1985). 1994 елдан РФА Уфа Гыйльми үзәгендә, Урал халыклары бүлеге фәнни хезмәткәре (1994–98), Этнологик тикшеренүләр ин-ты өлкән фәнни хезмәткәре һәм этнополитология бүлеге мөдире (2000 нән). Хезмәтләре Башкортстан халыкларының этносәяси тарихын, этносоциолингвистикасын өйрәнүгә карый. Башкортстанда 20 йөздәге этномәдәни һәм этносәяси процессларны тикшерә.

Х е з м.: Принципы этнополитического развития Башкортостана. М., 1997; Национальные отношения в Башкортостане. М., 2000; Этнополитическое развитие Башкортостана в XX веке: Социолингвистический аспект. К., 2004; Языковая политика в Башкортостане в XX веке: В 2 т. Уфа, 2007–08. Этническая и языковая идентичность в региональном измерении: феномен Башкортостана (1959–2002 гг.). Уфа, 2012 (автордаш).

*Әд.:* Сафин Фаиль Габдуллович: Библиогр. указ. Уфа, 2009.

**СА́ФИН** Факил Миңнемөхәммәт улы (әдәби тәхәллүсе Факил Әмәк) (2.1.1954, Мөслим р-ны Әмәкәй а.), язучы, филол. фән. канд. (2007), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1981). 1975 елдан Мөслим р-ны урта мәктәпләрендә укытучы. 1984 тән Чаллыда яши. 1988 гә кадәр «КамАЗ» ҖБдә мастер. 1991–95 тә «Аргамак» ж-лы мөхәррире һәм җаваплы сәркәтибе, 1996–99 да «Фән һәм мәктәп» — «Наука и школа», 2001–05 тә «Мәйдан. Чаллы» ж-лары баш мөхәррире. 2005–06 да ТР Язучылар берлеге рәисе урынбасары, 2006 дан шәһәр хакимияте каршындагы рухи мирасны өйрәнү төбәк фәнни-методик үзәге җитәкчесе. 1970 елларда яза башлый. «Тузганак чәчәге» (Чаллы, 1994), «Сәфәр» (2002) исемле шигырь җыентыкларында татар халкының язмышы турында уйланулар урын ала. Шигырьләре аллегорик сурәтләүләргә бай. «Соңгы көз» (Чаллы, 1992) повестенда кешенең тоталитар җәмгыятькә хас иллюзияләрдән арыну процессы тасвирлана. «Гөлҗиһан» хикәяләр җыентыгы мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек турында. «Биек тауның башларында» (1998) романында автор татар әдәбиятында беренчеләрдән булып 20 йөз ахырында Чечен Респ-касы б-н РФ арасында туган низагны чагылдыра. Төп геройлары репрессия корбаннарына әверелгән «Саташып аткан таң» (2003) роман-трилогиясе б-н «Шәүлә» (2008) романы да тарихи чынбарлыкка нигезләнеп иҗат ителә. Балалар өчен язылган «Ак канатлы йолдызлар» (1997), «Ләлә белән Арыслан» (2005) җыентыклары; К.Сибгатуллин, Зөлфәт, Р.Бәшәр, М.Әгъләмовның тормыш һәм иҗат юлларына багышланган әдәби-тәнкыйть мәкаләләре авторы. ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләге лауреаты (1999). Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б ә й р ә м о в а Г. Шәфкать һәм вәхшәт // Казан утлары. 1999. № 5; З а һ и д у л л и н а Д. Фаҗигале еллар авазы // Яңа дулкында. К., 2006; ш у л у к. Яңа юллар бәхете // Казан утлары. 2007. № 7.

**СА́ФИН** Фәйзрахман Әхмәтҗан улы (2.11.1925, Арча кантоны, хәзер Питрәч р-ны Шәле а. — 8.4.2010, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Казан пед. уч-щесен тәмамлый (1956). 1950–86 елларда Питрәч р-нында эшли: Шәле урта мәктәбендә укыта, «Чулпан» (Чита а., 1956 дан), Вахитов исем. (Шәле а., 1959–86) к-зларда рәис. С. җитәкче булганда, Вахитов исем. к-зда 4 мең урынлык мөгезле эре терлек өчен бина, ш.и. 1,2 мең баш сыер өчен ферма, дуңгыз һәм сарык фермалары, 3,5 мең *т* бәрәңге саклау урыны, мәктәп, мәдәният сарае, участок хастаханәсе һәм җитештерүнең башка объектлары, социаль-мәдәният һәм көнкүреш биналары төзелә; Шәле авылы һәм колхозына электр, радио, телефон, газ кертелә. Районда җитештерүнең алдынгы алымнарын кертү буенча төп хуҗалык булып тора, СССР, ТАССР ВДНХсында катнаша, Казан өчен сөт, бәрәңге, яшелчә җитештерү буенча респ-када иң зурлардан санала. Еллык сөт җитештерү 4–5 мең *т* га, бәрәңге — 7–8 мең *т* га, яшелчә — 2 мең *т* га, ш.и. суган — 500 *т* га җитә. Колхоз өч тапкыр КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның күчмә Кызыл Байрагы б-н бүләкләнә. 1975–81 елларда ТАССР ЮС депутаты,

рәис урынбасары. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале, РСФСР, ТАССР, ТР ЮС Президиумнарының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Каримов К.А. На берегах Мёши. К., 2006. *И.Н.Афанасьев.*

**СА́ФИН** Фәннур Шәйхенур улы (27.6.1948, Минзәлә р-ны Күзкәй а. — 31.12.1992, Казан), шагыйрь. Казан ун-тын тәмамлагач (1974), ТАССР МСның Телевидение һәм радиотапшырулар ком-тында мөхәррир, «Татарстан яшьләре» г-тасы, «Ялкын» һәм «Казан утлары» ж-лларында әдәби хезмәткәр, «Мәгариф» нәшриятында мөхәррир вазифаларын башкара. 1983–87 елларда ТАССР Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бюросы хезмәткәре. Башлангыч чор шигырьләре «Беренче карлыгачлар» (1970), «Юл башы» (1972) күмәк җыентыкларында урын ала. «Кеше юлга чыкса» (1976), «Сез кемнәр?» (1980), «Тынлык» (1982), «Күкчәчәк» (1985), «Чәчәк гомере» (1988) шигъри җыентыклары авторы. С., нигездә, лирик шагыйрь. Төп темасы — татар халкы язмышы, буыннар дәвамчанлыгы. Шигырьләренә халыкчан тел бизәкләре, моңсулык, сагыш б-н өртелгән җылылык хас. Балаларга атап язылган шигырьләре («Яңгыр малае», 1993) гадилеге, кызыклы булулары б-н аерылып торалар, яшь буынны кыю, гадел, кешелекле булырга өйрәтәләр. С. шигырьләренә иҗат ителгән «Хушлашырга ашыкма» (Р.Гатауллин музыкасы), «Җырымда юатырмын» (Б.Мөлеков музыкасы), «Моңлану» (Ф.Хатипов музыкасы) җырлары халык арасында киң тарала.

Әсәр.: Тынлык. К., 2008.

*Әд.:* Лерон Л. Йөрәктә ниләр бар? // Казан утлары. 1987. № 5; Гамбәр Н. Авырту булып калды // Казан утлары. 1998. № 6; Якупов К. Тынлыкка эндәшү // Мирас. 2002. № 12; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. 2 т.

**СА́ФИН** Шаһзам Сафа улы (7.4.1932, Горький өлкәсенең Краснооктябрьск р-ны Кочки-Пожарки а. — 23.3.1985, Мәскәү), спортчы (грек-рим көрәше), СССРның атказ. спорт остасы (1952). Мәскәү физик культура ин-тын тәмамлый (1953). Спорт б-н 1947 елда «Труд» ирекле спорт җәмгыятендә шөгыльләнә башлый (Мәскәү, тренеры — А.А.Гордиенко). СССР беренчелегендә (1950, яшүсмерләр арасында), бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивальләрендә (1951, 1953, 1955, 1957) җиңүче, Олимпия уеннары чемпионы (1952), СССР чемпионатында (1951), СССРның шәхси-команда беренчелегендә (1952) бронза медальләр ала, дөнья чемпионы (1953, 68 *кг* кадәрге үлчәү категориясендә). 1991 дән Мәскәүдә татар спорт көрәше буенча С. истәлегенә Бөтенроссия турниры уздырыла.

**СА́ФИНА** Асия Илдус кызы (29.9. 1961, Казан), педиатр, мед. фән. д-ры (2005). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1985), Казандагы балалар мед. учреждениеләрендә эшли. 1991 елдан Казан мед. академиясендә (бүленеп, 1993–97 дә ТРның Аналар һәм балалар сәламәтлеген саклау үзәгендә), 1997 дән педиатрия һәм неонатология кафедрасында, каф. мөдире, проф., проректор (2009). Хезмәтләре балаларда бөер зәгыйфьлеген тикшерүгә, балаларда пиелонефрит авыруы барышында бактериаль һәм вируслы инфекцияләрнең клиник-патогенетик ролен ачыклауга карый. Балалар нефрологиясе буенча дәреслек авторы. Уйлап табуга 2 патенты бар. РФ Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә (2011).

Хезм.: Бактериальные и вирусные инфекции в развитии и прогрессировании пиелонефрита у детей. К., 2010; Диагностический справочник в детской нефрологии. К., 2012 (автордаш); Классификация заболеваний в практике педиатра и неонатолога. К., 2012 (автордаш); Perinatal comprehensive strategy for management of neonatal respiratory distress syndrome in preterm infant: basic points of the European consensus. 2013. update // Вестник современной клинической медицины. 2013. Т. 6, вып. 6.

**СА́ФИНА** Динара Мөбин кызы (27.4.1986, Мәскәү), спортчы (теннис), Россиянең атказ. спорт остасы. Спорт б-н 1994 елда «Спартак» олимпия резервындагы махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр мәктәбендә шөгыльләнә башлый (Мәскәү); беренче тренеры — Р.Исламова (әнисе). 1999 елда Валенсия шәһәренә китә (Испания): 2000 нән теннисчы-профессионал, 2005 тән Россия җыелма командасы әгъзасы. Россия чемпионатында (1998, 14 яшькә кадәрге теннисчылар арасында ялгыз һәм парлы разрядларда), АКШның ачык чемпионатында (2007, парлы разрядта), «Зур Шлем» — «US Open» (2007, парлы разрядта), Хатын-кызлар теннис ассоциациясенең ялгыз разрядында 11 турнирда, парлы разрядта 8 турнирда (2002, Польша; 2003, Италия; 2005, Франция, Чехия; 2007, Австрия; 2008, Германия, АКШ, Канада, Япония; 2009, Италия, Испания) җиңүче. «Зур Шлем» — «Roland Carros» (2008, 2009), «US Open» (2008), «Australian Open» (2009), Уимблдон (2001, кыз балалар арасында) турнирларында, Франциянең ачык чемпионатында (2008, 2009) финалист. Олимпия уеннарында (2008, ялгыз разрядта) көмеш медальләр ала. Федерация Кубогы иясе (2005, Россиянең милли командасы составында). Ялгыз разрядта «Дөньяның өченче ракеткасы» (2008), 2009 да Хатын-кызлар теннис ассоциациясе рейтингында 1 нче урынны ала. 2014 тә спорт карьерасын рәсми рәвештә тәмамлый. 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орден медале б-н бүләкләнә. Монте-Карло шәһәрендә (Монако) яши.

**СА́ФИНА** Зөлфия Нурмөхәммәт кызы (6.11.1957, Чистай ш.), педагог, пед. фән. д-ры (2005), проф. (2008). 1980 елдан, Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында инструктор булып эшли, 1987 дән Чистай сәгать з-дының партия кабинеты мөдире. 1990 нан В.И.Ленин Үзәк музееның Казан ф-лында. Бер үк вакытта, 1990 нан, Татарстан Респ-касы социаль тикшеренүләр үзәгендә, 1993 тән РМАның Махсус урта белем бирү ин-тында фәнни хезмәткәр (Казан). 1996 дан Казан социаль-юридик ин-тының социаль эшләр ф-ты деканы. 1997 дән Татар эшмәкәрлеккә булышлык итү ин-тында: квалификация күтәрү ф-ты деканы, белгечләр әзерләү һәм яңадан әзерләү каф. мөдире (2002 дән) һәм Өзлексез белем бирү ин-ты директоры (2003). ТРның Иҗтимагый палатасы аппараты җитәкчесе (2009 дан). Хезмәтләре өлкәннәрне укыту методикасына карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Образование взрослых: перспективы для общества и человека. К., 2004; Становление региональной системы образования взрослых. К., 2005.

**СА́ФИНА** Нәҗибә Әхмәтнур кызы (2.3.1949, БАССРның Яңавыл р-ны Кисәк-Каен а.), шагыйрә. Казан ун-тын тәмамлагач (1972), Кама Тамагы, Чистай р-ннары урта мәктәпләрендә, Чистай пед. уч-щесендә укытучы булып эшли. 1979–90 елларда Башкортстанда яши: «Алга» Краснокамск район г-тасында хәбәрче, бүлек мөдире; 1983 тән Нефтекамск шәһәрендә автоүзбушаткычлар з-дында эшли; 1988–90 да шәһәрнең китап сөючеләр җәмгыятендә җаваплы сәркәтип. 1990 да кабат Казанга кайта. 1992–96 да «Шәһри Казан» г-тасында хәбәрче, «Сөембикә» ж-лында бүлек мөхәррире. Беренче шигырьләре көндәлек матбугатта, «Яшь көчләр» (Уфа, 1982), «Кызлар җыры» (1984) күмәк җыентыкларында басыла. Милләт язмышы турындагы публицистик рухлы һәм лирик шигырьләре «Таң кошы» (1997), «Әгәр дә уйлаганда...» (2002), «Без — шигырь, тормыш — проза» (2004), «Кан хәтере» (2009) исемле җыентыкларда тупланган. Аның публицистикасы да милләтне борчыган җитди мәсьәләләрне кыю күтәрүе, принципиаль карашлары б-н үзенчәлекле. Балаларга С. мавыктыргыч сюжетлы әкиятләре, шигырьләре тупланган «Кош теле» (1996), «Мәче фәлсәфәсе» (2000), «Аккош күле» (2000), «Камка һәм яфрак капка» (2004), «Чакырып алынган ай» (2009) исемле җыентыклары б-н мәгълүм.

*Әд.:* Гамбәр Н. Таң кошы — таңда йокламый... // Казан утлары. 2004. № 3.

**СА́ФИНА** Нина Павловна (3.12.1939, Казан), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008), техник фән. канд. (1985), ТАССРның атказ. химигы (1991). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), шунда ук ясалма каучук кафедрасында эшли. 1972 елдан ябык Идел-Кама «Кварт» резинотехника АҖнең үзәк лаб-ясендә өлкән инженер, башлык урынбасары. Уйлап табуга 27 авторлык таныклыгы һәм 2 патенты бар. Дәүләт бүләге Татарстанда җитештерелгән эре тонналы полимерлар нигезендә динамик термоэластопластлар — яңа буын композицион материаллар җитештерүне оештыруда һәм эшләүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**СА́ФИНА** Фәридә Мирхафизан кызы (20.3.1957, Сарман р-ны Сарман а.), драма актрисасы, ТРның халык артисты (2015). Казан театр уч-щесен (1985), Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тын (оештыручы-методист

һәм вокал сәнгате белгечлекләре буенча, 1978, 2005), Казан ун-тын (музыка гыйлеме белгечлеге буенча, 2014) тәмамлый. 1985 елдан Татар акад. театрында эшли. С.ның күпкырлы иҗади сәләте драма, комедия, муз. драма жанрларының барысында да бертигез дәрәҗәдә ышандырырлык итеп ачыла. Актрисаның Зөбәрҗәт («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), ирдәүкә Фәүзия («Казан егетләре», «Тагын Казан егетләре», М.Гыйләҗев), Гафифә («Каениш, көндәш һәм башкалар», Г.Камал) кебек үткен характерлы рольләре тамашачы тарафыннан яратып кабул ителә. Актриса классик драматургия репертуары буенча да уңышлы образлар тудыра: Гөлчирә («Әни килде», Ш.Хөсәенов), Мәйсәрә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Галиябану (шул исем. әсәр буенча, М.Фәйзи), Гөлемхан («Ахырзаман», Ч.Айтматов әсәре буенча) һ.б. Башка рольләре: Анук, Фаягөл («Гөргөри кияүләре», «Алты кызга бер кияү», Т.Миңнуллин), Виктория («Булмас димә, дөнья бу!», А.Вампилов), Мария-Каролина («Гаугалы гаилә», Э.де Филиппо), Сәмидә («Кичер мине, әнкәй!», Р.Батулла), Сәвия («Мәхәббәт турында сөйләшик», И.Зәйниев). Бер үк вакытта Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында укыта (2003–11).



Ф.М. Сафина.



Ф.М. С а ф и н а Мәйсәрә ролендә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин).

*Әд.:* И л я л о в а И.И. Она рискует и выигрывает. Хотя и не пьет шампанское // Казань. 2008. № 1.

**СА́ФИНА** Фирсинә Шәймулла кызы (15.10.1938, Казан — 24.3.2008, шунда ук), этнограф, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999), тарих фән. канд. (1990). Казан ун-тын тәмамлый (1969). 1970–96 елларда ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1997 дән Тарих ин-тында. Хезмәтләре татар халык кәсепләре тарихын өйрәнүгә карый. Дәүләт бүләге «Идел буе һәм Урал татарларында тукучылык (XIX йөз ахыры — XX йөз башы): Татар халкының тарихи-этнографик атласы» («Ткачество татар Поволжья и Урала (конец XIX — начало XX вв.): Историко-этнографический атлас татарского народа», 1996) монографиясе өчен бирелә.

Х е з м.: Узорное ткачество татар: Очерки по истории татарской культуры (в контексте «Запад»-«Восток»). К., 2001.


**СА́ФИНА** Чулпан Марат кызы (3.1.1967, Казан — 2.2.2012, шунда ук), микробиолог, вет. фән. д-ры (2012). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1989), шунда ук микробиол. һәм вирусология кафедрасында эшли. Хезмәтләре уңышлы эшләүче хуҗалыкларда туберкулинга нәспецифик аллергия реакцияләре очракларында микрофлораны өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Аэрозольная профилактика заболеваний норок при промышленной технологии производства шкурок в закрытых помещениях // Ветеринарный врач. 2000. № 2 (автордаш); Возбудители микроплазмов, хламидиозов и риккетсиозов. К., 2001 (автордаш); Эпизоотическое состояние по туберкулёзу скотоводческих предприятий Республики Татарстан // Уч. зап. Казанской академии вет. медицины. 2002. Т. 172 (автордаш).

**САФИУ́ЛЛИН** Әнәс Гадел улы (23.2.1947, Әтнә р-ны Олы Әтнә а.), компрессорлар төзүче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005), техник фән. канд. (2004), ТРның атказ. машина төзүчесе (2006). 1970 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1964–65 тә Казан компрессорлар з-дында эшли. 1965 тән компрессорлар төзү махсус КБсында (хәзер «НИИтурбокомпрессор» АҖ), бюро, бүлек башлыгы, баш конструктор (1985–97), директор урынбасары (1997 дән), ген. директор урынбасары (1999 дан). Хезмәтләре яңа компрессорлар техникасын булдыруга карый. С. җитәкчелегендә үзәктән куулы компрессорларны көйләү, машиналарның югары эффектив агым уздыру өлешләрен төзү буенча тикшеренүләр алып барыла; үзәктән куулы компрессорларны көйләүнең отышлы ысуллары, 6,3 тән 16 *МВт* ка кадәр егәрлекле газ кудыру агрегатларында төрле типтагы кудыргычларның алмаш агым өлешләре эшләнә; Шахтинск, Каменск, Төмән, Уфа, Казан һ.б. шәһәрләр ТЭЦларында кулланыла торган газ турбиналы двигательләргә ягулык газы бирү өчен үзәктән куулы һәм калаклы компрессор җайланмалары үзләштерелә. Дәүләт бүләге газ кудыру агрегатлары кудыргычларына нәтиҗәле алмаш агым уздыру өлешләрен эшләүдә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медаль б-н бүләкләнә. РФ Сәнәгать, фән һәм технологияләр министрлыгының мактаулы машина төзүчесе (2004).

Х е з м.: Новое компрессорное оборудование для газлифтной добычи нефти // Компрессорная техника и пневматика. 1993. № 2 (автордаш); Исследование регулирования ступени многовального центробежного компрессора // Компрессорная техника и пневматика. 2001. № 6; Разработка и освоение холодильных машин на базе многовальных мультипликаторных компрессоров для предприятий нефтяной, газовой и химической промышленности // Холодильная техника. 2007. № 1 (автордаш).

**САФИУ́ЛЛИН** Әнвәр Шакирҗан улы (2.7.1927, Бөгелмә кантоны Әлмәт а.), нефтьче, Соц. Хезмәт Герое (1973), ТАССРның атказ. нефтьчесе (1972). Бораулау осталары мәктәбен тәмамлый (1971). 1951–64 елларда «Татнефть» берләшмәсенең «Әлмәтнефть» нефть промыселы идарәсендә нефть һәм газ чыгару операторы ярдәмчесе, оператор, мастер булып эшли; 1964 тән «Татнефтепроводстрой» трестының 2 нче механикалаштырылган колонна башлыгы, 1966 дан өлкән прораб, 1969–87 дә комплекслы-технол. агым башлыгы. Герой исеме 1973 елга кабул ителгән соц. йөкләмәләрне үтәгәндә ирешкән уңышлары өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә. Әлмәт шәһәренең мактаулы гражданы (1972).



Ә.Ш. Сафиулин.

*Әд.:* З а р и п о в И.Х. Мастер. К., 1979; Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Л а р и ч е в а Э.И. Дороже золота. К., 1988; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**САФИУ́ЛЛИН** Әхәт Хафизулла улы (26.12.1936, Украина ССР, Донецк өлкәсенең Путиловка р-ны Путиловка пос.), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1998). Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый (1966). 1956–92 елларда Казанның төрле төзелеш оешмаларында мастер, прораб, инженер булып эшли. 1992–96 да «Чаян» ж-лында мөхәррир. 1960 елларда яза башлый. Яшь төзүчеләр тормышыннан алынган «Язларында ялгыз йөрсәң...» (1982), «Онытылган вәгъдә» (1986) исемле хикәяләр һәм повестьлар җыентыклары, Г.Рәхимкулов турында «Моңлы бер җыр булып...» (2001) исемле истәлекләр, «Йомгак очы» (2002) маҗаралы повесть, «Туган якның таң җилләре» (2002) шигырьләр җыентыгы авторы. Сатира һәм юмор жанрындагы әсәрләре «Сер бирмәдек» (1997), «Тулгана дөнья» (2000), «Җиденче буын» (2006) җыентыкларында тупланган.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**САФИУ́ЛЛИН** Гани Биккенә улы (1.7.1905, Казан губ., Казан өязе Иске Кишет а. — 14.10.1973, Казан), генерал-лейтенант (1945), Сов. Союзы Герое (26.10.1943). 1926–27 елларда Семипалатинск (Казакъстан ССР) шәһәрендә Бухтарма өяз комсомол ком-тында инструктор булып эшли. Запастагы взвод командирлары мәктәбен (1928), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (Мәскәү, 1941), К.Е.Ворошилов исем. СССР Кораллы Көчләре Генштабының Хәрби академиясе каршындагы Югары акад. курсларын (Мәскәү, 1947) тәмамлый. 1927 дән Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 38 нче укчы дивизия һәм 25 нче гв. укчы корпусы командиры (7 нче гв. армиясе). С. дивизиясе Сталинград янындагы сугышта дошманның 18 меңнән артык солдат һәм офицерын әсир төшерә. Дон, Во-

ронеж, Дала һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Сталинград сугышында (1942–43), Кировоград (1944), Яссы-Кишинёв (1944), Будапешт (1944–45), Прага (1945) һөҗүм операцияләрендә һәм япон гаскәрләренә каршы сугышта (1945) катнаша. Днепр елгасын кичеп, Бородаевка һәм Домоткань (Украина ССР, Днепропетровск өлкәсенең Верхнеднепровский р-ны) авыллары янындагы сугышта батырлык күрсәтә. 1943 нең 25–30 сентябрендә С. җитәкчелегендәге солдатлар төркеме елганы кичеп чыга. Дошманның өзлексез һөҗүменә каршы торып, яуланган плацдармның буен 25 *км* га, иңен 15 *км* га зурайта һәм, төп көчләр килгәнче, аны кулда тотып тора. 1957 дән запаста, Казанда яши, Сугыш ветераннары советы рәисе булып эшли. Ике Ленин ордены, өч Кызыл Байрак, ике 2 нче дәрәҗә Суворов, ике 2 нче дәрәҗә Кутузов орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Сугыш турында мемуарлар авторы. Казанда бер урам С. исеме б-н атала, Иске Кишет авылында С. музее ачыла.



Г.Б.Сафиуллин.

Х е з м.: Через реки, через горы... К., 1973; Дорогами Победы. К., 1987.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**САФИУ́ЛЛИН** Данияр Илгизәр улы (12.2.1962, Сәмәрканд ш., Үзбәкстан ССР), генерал-майор (2003). Алма-Ата гомумгаскәр командирлар югары уч-щесен (1983), РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Гражданнар саклау академиясен (Мәскәү өлкәсе Химки ш., 2001) тәмамлый. 1983–92 елларда СССР һәм РФ Кораллы Көчләрендә җитәкче вазифалар башкара. 1992–96 да Алма-Ата Гражданнар оборонасы органнарында җаваплы эшләрдә: штаб башлыгы — Алатау р-ны башлыгы урынбасары, әзерләү һәм өйрәтү бүлеге башлыгы. 1996 дан РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы системасы хезмәтендә: 1996 дан 177 нче аерым коткару бригадасы командиры (Железногорск ш.) штабы башлыгы — командир урынбасары, 1999 дан башлык урынбасары, 2008–09 да гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-казаларны бетерү эшләре буенча Себер төбәге үзәге башлыгының 1 нче урынбасары, 2009 ның мартыннан башлыгы (бүленеп: 2002–08 дә РФ Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-казаларны бетерү эшләре министрлыгының Новосибирск өлкәсе буенча Баш идарәсе башлыгы). 2001 дә Ленск шәһәрендәге (Саха-Якутия Респ-касы) су басуларны бетерү өчен җыелма мобиль отряд әзерләү эшенә җитәкчелек итә. 2003 тәге җир тетрәүләрдән соң Алтай Респ-касы халкына гуманитар йөк, төзелеш материаллары җыю һәм тапшыру эшен оештыруда, 2009 да Саян-Шушенский ГЭСындагы (Хакасия Респ-касы) аварияне бетерүдә катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

**САФИУ́ЛЛИН** Ким Мөхәммәт улы (26.6.1927, Курган өлкәсенең Әлмән р-ны Туз а.), монументалист, нәкышьче, график, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1996). Дүшәнбе сәнгать уч-щесен тәмамлый (1958), В.И.Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тында укый (1958–62). 1962 елдан — Таҗикстан ССР Сәнгать фондында, 1969–71 дә ТАССР Сәнгать фондында эшли. 1971–92 дә Татарстан Сәнгать фондының Чаллы сәнгать-җитештерү участогында. 1996–2004 тә Чаллы пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тында укыта. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1992). С. Чаллы шәһәрендәге яңа төзелешләрнең һәм КамАЗ объектларының сәнгать бизәлешенә күп өлеш кертә; Татарстанның көньяк-көнчыгыш шәһәрләрендәге, ш.у. Казан, Дүшәнбе, Ташкенттагы байтак кына җәмәгать биналары экстерьер һәм интерьерларында урын алган әсәрләр авторы. Аның дивар композицияләре һәм паннолары смальта һәм керәч мозаика, темпера, майлы буяу һәм балавыз б-н язылган нәкышь, гипска, агачка уеп, язып төшерелгән бизәк, пыялага ком сиптереп ясалган гравюра һ.б. техникаларда башкарылган. Төп әсәрләре: Ташкентта торак йортлар фасадларындагы металл паннолар (Чиланзар микрор-ны, 1967), Дүшәнбе шәһәренең балалар бакчасы фасадындагы таҗик



К.М.С а ф и у л л и н. «Мәңгелек җир». Фреска. Мәктәп интерьеры. Тукай районының «Татарстан» совхозы посёлогы. 1976.

әкиятләре темаларына коры фреска (сыек пыяладан), Т.Шевченко исем. пед. ин-ты интерьерларындагы темпера нәкыше (1950–60 еллар), Казан автовокзалы интерьерындагы «Татарстан юллары» коры фрескасы (1969–70, рәссам В.К.Фёдоров б-н бергә). Чаллы шәһәр башкарма к-ты утырышлар залы өчен коры фреска техникасында «Ленинизм байрагы» дигән дивар бизәге (Х.М.Гыймазетдинов б-н бергә), «Кама» рестораны залында таш һәм керәч мозаика (1972), 12 нче мәктәптә гипска уеп «Галәм һәм кеше» дивар паннолары (1973) һ.б.ны ясый. С., респ-када беренче булып, керәч плитә өслеген яндыру алымы б-н бизәк төшерү техникасын үзләштерә, Чаллыдагы балалар бакчасының йөзү бассейнын (1975), Тукай р-ны «Татарстан» совхозы посёлогының урта мәктәп бинасын («Минем Ватаным» һәм «Мәңгелек җир» паннолары), терлекчелек комплексы идарәсенең актлар залы интерьерларын (барысы да — 1976) бизи. С.ның дивар композицияләренә татар халык сәнгате стилистикасына нигезләнгән ачык төсләр һәм образлы чишелешләр, шәрекъ миниатюралары традицияләрен үстерүче фәзаи төзелешләр, реалистик мәктәпнең сюжетлы-фигуралы нәкышь үзенчәлеге хас.

С. станлы картиналар үсешенә өлеш кертә. Таҗикстанда 20 елдан артык эшләү нәтиҗәсендә ул зур күләмле картиналар галереясын, көньяк чикләрнең пейзажлар сериясен тудыра («Шәрекъ базары», 1957; «Дүшәнбе» этюдлар сериясе, 1959–69; «Баш бала», «Чор-Мазак кышлагы», 1960 еллар). Татарстанда С. баштарак көнкүреш картиналары һәм портретлар — «КамАЗ төзүчеләр» (1972–78), «КамАЗның металл коючылары» (1974), «Улыма. КамАЗга» (1975), «КАМАЗлар Чор-Мазак үткелендә» (1975–78), «Е.Н.Батенчук портреты» (1982) сериясен иҗат итә. 1990 еллардан милли темага мөрәҗәгать итә, тарихи жанрда эшли (аерым алганда, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы турындагы картиналары); кайбер әсәрләрен катнаш техникада фанерада башкара — 16 йөз шагыйре Мөхәммәдъяр портреты (1998) һ.б. Татар мәдәнияте эшлеклеләре С.Җ.Сәйдәшев, Ф.Ә.Бәйрәмова (икесе дә — 1997), Сов. Союзы Геройлары Н.Я.Якупов, И.М.Маннанов (икесе дә — 1995) портретлары авторы. Графика өлкәсендә С. карандаш рәсемнәре («Айни», 1951–62; «Хатыным портреты», 1974; «Иске Чаллы» сериясе, 1975–78), линогравюралар («Чишмәдән кайтканда», 1958–59; «Тау миражы», 1958), плакатлар һ.б.ны иҗат итә.

Респ-ка — Дүшәнбе (1959 дан), Казан һәм Чаллы (1972 дән), «Совет Татарстаны» (Ленинград, 1972), зона — «Зур Идел» (Волгоград, 1967), төбәк — «Алтын Урда» (Казан, 1993) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Чаллыда (1997, 2003, 2007), Уфада (1999) уздырыла.

Әсәрләре Дәүләт Тарих музеенда (Мәскәү), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, К.Бәхзадә исем. Дәүләт берләштерелгән тарих-туган якны өйрәнү һәм сынлы сәнгать музеенда (Дүшәнбе), Чаллы шәһәре Картиналар галереясында, шәхси тупланмаларда саклана.

Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х ө р м ә т о в а Н. Хыял кошы // Аргамак. 1994. № 10; В ә л и е в а - С ө л ә й м а н о в а Г.Ф. Монументально-декоративное искусство Советской Татарии. К., 1984; С у л т а н о в а Р.Р. Искусство новых городов Татарстана. К., 2001.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**САФИУ́ЛЛИН** Ленар Наил улы (5.8.1975, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2007). Казан техник ун-тының радиотехника ф-тын тәмамлаганнан соң (2000), шунда ук икътисади теория һәм хокук кафедрасында эшли. 2002 елдан Казан аграр ун-тында, икътисади анализ каф. мөдире (2007–11). 2011 дән Идарә итү һәм терр. үсеш ин-тының (хәзер Казан ун-тының Идарә итү, икътисад һәм финанс ин-ты) директор урынбасары, бер үк вакытта (2011 дән) икътисади методология һәм үсеш каф. мөдире. Хезмәтләре иҗтимагый байлыкны үстерү, хуҗалык итү субъект һәм объектларының көндәшлеккә сәләтен арттыру, продукциянең сыйфаты б-н идарә итү мәсьәләләренә карый. С. ТРда-



М.Р. Сафиуллин.

гы хуҗалык итү субъектларының көндәшлеккә сәләтен ачыклау (диагнозлау) ысулларын эшли.

Х е з м.: Конкурентные преимущества и конкурентоспособность. К., 2002 (автордаш); Качественная основа благосостояния // Экон. науки. 2005. № 3; Общественное благосостояние в условиях неоднородности рынков. К., 2006; Оценка конкурентоспособности хозяйствующих субъектов // Вестн. Казан. гос. аграрного ун-та. 2007. № 5.

**САФИУ́ЛЛИН** Марат Рәшит улы (24.9.1970, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1995), ТР ФА хакыйкый әгъзасы (2000). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). 1991 елда Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (2007 гә кадәр), менеджмент каф. мөдире (1998 дән). ТРның тышкы икътисади элемтәләр министры киңәшчесе (1991–97), «КамАЗ» АҖ директорлар советының финанс ком-ты рәисе урынбасары (1997–98), ТР МК каршындагы Кыйммәтле кәгазьләр һәм фонд базары комиссиясе секретаре (1997–2002). ТР Президентының социаль-икътисади (2003–06), икътисад (2006–07) мәсьәләләре буенча дәүләт киңәшчесе. 2007–10 елларда ТРның икътисад министры, 2010 нан Казан ун-ты проректоры, бер үк вакытта ТР ФАнең Перспективалы икътисади тикшеренүләр үзәге директоры. Хезмәтләре терр. икътисади системалар б-н стратегик идарә итү, икътисади эшчәнлек төрләренең конкурентлыкка сәләтлелеге б-н идарә итү, макроикътисади модельләштерү һәм прогнозлау мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Современные проблемы регулирования рынка труда. К., 1999; Методология разработки стратегических программ социально-экономического развития территории. К., 2005; Разработка развития Республики Татарстан. К., 2007 (автордаш).

**САФИУ́ЛЛИН** Наил Әхмәт улы (22.12.1937, Мамадыш ш.), инженер-механик, а.х. фән. д-ры (2003), проф. (2004), ТАССРның атказ. механизаторы (1988). РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2002). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1961). Яшел Үзән р-нының Ленин исем. тәрәк-үрнәк хуҗалыгында (1961–63), «Приволжье» к-зында (1963–64) баш инженер булып эшли. 1964–2003 елларда (бүленеп) Казан вет. медицинасы академиясендә, механикалаштыру каф. мөдире (1982 дән), бер үк вакытта проректор (1999–2003). 1968–77 дә Казан а.х. ин-тында. С. башмак таналарның җиленнәрен массажлау һәм сыер саву өчен терлекләрнең физиол. үзенчәлекләренә яраклашкан җайланмалар эшли. Уйлап табуга 26 патенты һәм авторлык таныклыгы бар. ТР Дәүләт бүләге «Агросәнәгать комплексында микотоксикозларга диагноз кую, профилактикалау һәм дәвалау чараларын эшләү һәм гамәлгә кертү» эше өчен бирелә.

Х е з м.: Справочник фермера-животновода. К., 1993 (автордаш); Управление процессами совершенствования дойного стада и технологии получения молока. К., 1997 (автордаш); Резервы повышения эффективности отрасли молочного скотоводства. К., 2007 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**САФИУ́ЛЛИН** Наил Закир улы (28.8.1946, Кама Тамагы р-ны Иске Барыш а.), радиоэлектроника, икътисад теориясе өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1992), икътисад фән д-ры (2003), проф. (1993), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2001). 1974 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, радиоэлектрон чаралар технологиясе каф. мөдире (1994 тән). 2003 тән Казан аграр ун-тының икътисад теориясе каф. мөдире. Хезмәтләре мәгълүмати радиосистемаларның ихтималый катнашмалар һәм нәсызыкча функционаллар кулланылган статистик теориясенә карый. С. бүленеш катнашмаларын һәм Винер–Вольтерр функциональ тарткатмаларын куллану нигезендә нәсызыкча динамик системаларга анализ үткәрә; продукциясе һәм икътисади агентлары тамырдан бериш булмаган базарның үзенчәлекләрен тикшерә. Базарлар теориясен һәм методологиясен эшли, сорау һәм тәкъдимнең күп үлчәмле аддитив һәм нәсызыкча модельләрен төзи. Уйлап табуга 35 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Анализ стохастических систем и его приложения. К., 1998; Многомерный рынок: теория и методология. К., 2002; Рынок труда и качественная неоднородность. К., 2007 (автордаш); Потребительский спрос в экономике знаний. К., 2011 (автордаш).

**САФИУ́ЛЛИН** Наил Хәмит улы (23.9.1948, Казан), хокук белгече, педагог, генерал-майор (2000), юридик фән. канд. (1995), проф. (2002), ТРның атказ. юристы (1990), РФнең атказ. эчке эшләр органнары хезмәткәре (2002). Казан авиация ин-тын (1976), СССР Эчке эшләр министрлыгы академиясен (1986) тәмамлый. 1978 елдан Эчке эшләр министрлыгы органнарында: автоинспектор, ТАССР Дәүләт автоинспекциясе бүлеге башлыгы урынбасары, 1988 дән ТАССР, ТР эчке эшләр министры урынбасары, 1989 дан 1 нче урынбасары. 1993 тән РФ Эчке эшләр министрлыгы Юридик ин-тының Казан ф-лы башлыгы (1999 дан *Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты*). С. җитәкчелегендә пед. коллектив формалаша, ин-тның матди базасы ныгытыла — югары уку йорты ТР Эчке эшләр министрлыгы өчен кадрлар әзерләүче зур үзәккә әверелә. 2008 дән РФ Юстиция министрлыгының ТР буенча Федераль идарәсе җитәкчесе. 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены, медальләр, корал б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Прогнозирование преступности. К., 1999 (автордаш); Терроризм: История и современность. К., 2002; Социология девиантного поведения. К., 2006 (автордаш).

**САФИУ́ЛЛИН** Нур Шәфигулла улы (1.1.1914, Казан губ., Тәтеш өязе Бәки а. — 2.9.1997, Харьков ш.), химик, техник фән. д-ры (1966), проф. (1980), Украина ССРның атказ. уйлап табучысы (1969). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1937), Украина ССРның Донецк өлкәсе Константиновск химия з-дында эшли. 1957 елдан Харьков төп химия фәнни-тикшеренү ин-тының минераль тозлар һәм к-талар лаб-ясе мөдире, 1971–89 да Харьков тимер юл транспорты инженерлары ин-тында химия каф. мөдире. Хезмәтләре нәорганик кушылмалар химиясенә һәм технологиясенә карый. С. күкерт к-тасын һәм барий тозларын җитештерү технологияләрен камилләштерә (эшкәртмәләре әлеге матдәләрне чыгару цехларын проектлауда һәм төзүдә кулланыла). 130 дан артык фәнни мәкалә авторы. Уйлап табуга 65 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**САФИУ́ЛЛИН** Рафаил Кәрим улы (29.12.1948, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (2006). 1971 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1976–78 дә Казан авиация ин-тында. 1978 дән Казан архит-ра-төзелеш ун-тында, проф. (2007 дән). Хезмәтләре ТМРны тикшерүгә, газ бушанулары физикасына карый. С. тигезләнмәсез тирбәнү агымында буйга пыскулы бушану процессын ике үлчәнештә исәпләү мәсьәләсен куя һәм чишә. Мөстәкыйль булмаган бушануда корылган плазма компонентларының һәм электр кыры потенциалының фәзаи бүленешен саннарда исәпләү алгоритмын һәм программасын эшли. Газ агымында һәм бушану камераларында буйга һәм аркылыга пыскулы бушанулы $CO_2$-лазерларны исәпләүнең матем. модельләрен һәм исәпләү алымнарын үстерә.

Х е з м.: Физика вокруг нас. М., 1998 (автордаш); Численное моделирование электроионизационного и проточного электроразрядного СО-лазеров // Квантовая электроника. 2001. Т. 31, № 8 (автордаш); К расчёту камер с поперечным тлеющим разрядом в потоке электроотрицательного газа // Изв. вузов. Проблемы энергетики. 2003. № 3/4.

**САФИУ́ЛЛИН** Рәфгать Фәйзулла улы (10.3.1929, Чистай кантоны Коры Көрнәле а. — 13.2.1995, Казан), хакимият-хуҗалык җитәкчесе, РСФСРның атказ. сәүдә хезмәткәре (1985). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1958). 1954 елдан Иске Салман, Урта Тигәнәле, Коры Көрнәле авылларында укыта, КПСС район ком-тының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире урынбасары (1957 дән), секретаре (1959 дан), Алексеев район башкарма ком-ты рәисе (1962), Чистай район башкарма ком-ты рәисе (1962 дән); 1970 тән «Татпотребсоюз» идарәсе рәисе, 1992–95 тә «Татинкооп» АҖ президенты. С. җитәкче булганда, кулланучылар кооперациясе системасы б-н идарә итүдә үзгәрешләр уздырыла, вак авыл кулланучылар җәмгыятьләре бетерелә, 51 зур район кулланучылар җәмгыяте (райпо), 9 ярдәмче хуҗалык булдырыла. Барлык район кулланучылар җәмгыятьләрендә

кибетләр, универсамнар, сәүдә үзәкләре, җәмәгать туклануы пр-тиеләре, ипи заводлары, а.х. продукциясен эзерләү һәм эшкәртү объектлары, колбаса, кондитер ризыклар һәм консерв әзерләү цехлары төзелешләре алып барыла. 1970–90 да кулланучылар кооперациясенең товар әйләнеше 543,1 млн. сумнан 1390,4 млн. сумга арта. 1963–67, 1971–75, 1980–85, 1985–90 да ТАССР ЮС депутаты, 1989–91 дә СССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б а я з и т о в К.С., Ш а к и р о в Р.В. Больше века на службе людям (Из истории потребительской кооперации Республики Татарстан). К., 1995. *И.Н.Афанасьев.*

**САФИУ́ЛЛИН** Рәшит Тәлгать улы (24.2.1949, Бөгелмә ш.), дизайнер, театр һәм кино рәссамы, график, нәкышьче. Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый (1968). 1972–76 елларда СССР Рәссамнар берлегенең Үзәк укыту-тәҗрибә студиясендә Е.А.Розенблюм җитәкчелегендәге сәнәгать һәм бизәү сәнгате рәссамнарының югары курсларында укый. 1968–69 да Әлмәт шәһәрендәге сәнгать мәктәбендә, 1970–73 тә Казан сәнгать уч-щесендә укыта. 1970–93 тә Татар сәнгать фондында эшли (бүленеп). 1981–83 тә Казан яшь тамашачылар театрының баш рәссамы. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1977). 1980 нән Мәскәүдә яши.

С. иҗат юлын 1974 тә «17 төркеме»нә берләшкән проектлаучы-рәссамнар төркемендә (В.Бойко, Е.Голубцов, А.Леухин, В.Нестеренко һ.б.) башлый. 1970 елларда Казандагы «Наратлык» кафесы (1972), вузара ашханә (1976), «Бегемот» сыра бары (1977) интерьерларын бизи. Дизайнчылар коллективы составында Кишинёв шәһәрендәге Гамәли сәнгать һәм халык иҗаты музее комплексларын (1972), Яңа Кырлай авылындагы Г.Тукай Музей-комплексын (1974–75), Мәскәүдә А.И.Герценның музей-фатирын, А.С.Пушкинның музей-йортын (1975–76) проектлауда, Монголия Халык Респ-касы төзелүгә 50 ел тулу уңаеннан Улан-Батор шәһәрен бәйрәмчә бизәүдә (1974), Әлмәт шәһәренең «Нефтьче» мәдәният сарае каршындагы үзәк мәйданны һәм экстерьерларны төзекләндерүдә һәм бизәүдә (1977) катнаша. 2000 елларда яңадан интерьерлар дизайнына мөрәҗәгать итә, декоратив бизәү б-н шөгыльләнә: кафе һәм рестораннар (Мәскәүдә — «Панчо Вилла», 2001); «Тапа де Комида», 2005; «На Большом Каретном», 2006; Парижда — «Восточный», 2006), экспозицияләр («Кавказ хатын-кызлары» күргәзмәләре — Мәскәү, Яңа Манеж, 2004, 2006; реж. А.А.Тарковский иҗатына багышланган юбилей күргәзмәләре — Мәскәү, Кино йорты, 2002; Зур Манеж, 2002; Әдәбиятчыларның үзәк йорты, 2004; Милләтләр йорты, 2007) бизи. С.В.Образцов исем. Курчак театрындагы «Куклы» рестораны (2002), А.А.Тарковский Тарихи-мәдәни музееның даими экспозициясе (Кострома өлкәсенең Кадый р-ны Завражье а., 2004) интерьеры авторы.

Театр рәссамы буларак, С. Мәскәүдәге Ленин комсомолы исем. театрда У.Шекспирның «Гамлет» (1977); Казан яшь тамашачылар театрында Я.Корчакның «Король Матиуш I» (1979), А.Володинның «Сөйгәннәрегез белән аерылмагыз» («С любимыми не расставайтесь», 1980), У.Шекспирның «Җәйге төндә күргән төш» («Сон в летнюю ночь», 1982) әсәрләре буенча куелган спектакльләргә, Татар опера һәм балет театрында С.Рахманиновның «Алеко» операсына (1983) декорацияләр ясый. «Сталкер» фильмының рәссамы (1979, реж. А.Тарковский), «Урак өсте» («Время жатвы») фильмының (2004, реж. М.Разбежкина), «Гармунчы» («Гармонист») мультфильмының (2003, реж. С.Быченко) куючы рәссамы; «Төш» («Сон») фильмына эскизлар авторы (1980, «Әрмәнфильм» киностудиясе, реж. А.Агаранян); А.Тарковскийның юбилей кичәсе өчен «Андрей» видеоклипы рәссамы (2004, Мәскәүдәге Әдәбиятчыларның үзәк йорты).

С.ның нәкышь һәм график хезмәтләре образлы кинаяләр, шигъри күзаллаулар б-н аерылып тора. Станлы нәкышьтә тематик картиналар һәм пейзажлар: «Ишекләр» (1989), «Ике көймә» (1990), «Көтү» триптихы (1991), «Зөя Апокалипсисы» (2001) серияләрен иҗат итә. «Тукай-Кырлай», «Яңа Кисекбаш» (1975–76), «Зөя Апокалипсисы» (1987–88) график картиналары һәм серияләре авторы. Китап графикасы һәм полиграфия дизайны өлкәсендә Татарстан китап нәшриятында («Чуртан кушуы буенча» рус халык әкияте, 1978; И.Нефёдовның «Әкият туган җирдә» — «Где рождается сказка», 1979; Ж.Дәрзамановның «Төнге әкият», 1980; В.Бәшировның «Дикобраз һәм корабль» — «Дикобраз и корабль», 1982), Мәскәү нәшриятларыннан «Молодая гвардия»дә (Р.Бохараевның «Кар торнасы», 1986), «Фортуна ЭЛ»дә («Кавказ хатын-кызлары» — «Женщины Кавказа», 2008) дөнья күргән китапларга иллюстрацияләр авторы буларак билгеле.

Респ-ка (1972 дән), бөтенроссия — «Рәссамнар — 9 нчы бишьеллыкның яңа төзелешләренә» (Мәскәү, 1974), бөтенсоюз — СССР Рәссамнар берлегендәге Үзәк укыту-тәҗрибә студиясенең проектлау эшләре (Мәскәү, 1975), бөтентатар — «Татарт» (С.-Петербург–Казан, 1991); халыкара — «Шәһәр мохитен проектлау» (Венеция ш., Италия, 1976), «Сталиннан Горбачёвка кадәр» (Тампере ш., Финляндия, 1989) биеннале-күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Мәскәүдә уздырыла (1998, 2003, 2005). Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, А.А.Бахрушин исем. театр музеенда, Дәүләт әдәбият музеенда, Мәскәүдәге Кино музеенда; чит илләрдәге шәхси тупланмаларда саклана.


*Әд.:* У в а р о в а И. Пушкинская тропа // Декоративное искусство. 1976. № 6; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. Монументально-декоративное искусство Советской Татарии. К., 1984; ш у л у к. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995. *Г.Р.Фәйзрахманова.*

**САФИУ́ЛЛИН** Рөстәм Сафиулла улы (1.5.1959, Минзәлә ш.), фармацевт, мед. фән. д-ры (1996), проф. (2002), ТРның атказ. сәламәтлек саклау хезмәткәре. Пермь фарм. ин-тын тәмамлаганнан соң (1981), БАССРда провизор, аптека мөдире булып эшли. 1985 елдан ТАССР МС карамагындагы Аптека идарәсенең Бөгелмә районара конторасы мөдире. 1989 дан «Татарстанфармация» пр-тиесе ген. директоры урынбасары, 1992 дән ген. директор. 1993 тән Казан мед. ун-тында, 1996 дан фармация идарәсе һәм икътисады каф. мөдире. 1997 дән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы Фармация департаменты башлыгы, бер үк вакытта, 2001 дән, фармация һәм мед. техникасы буенча сәламәтлек саклау министры урынбасары. Хезмәтләре дару ярдәме күрсәтүнең сыйфаты б-н идарә өлкәсендә норматив-хокукый мәсьәләләрне көйләүнең теоретик һәм оештыру-методик нигезләренә карый. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004). ТР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нормативно-правовое регулирование управленческих функций в системе лекарственного обеспечения населения Татарстана // Фармация. 2000. № 2; Формулярная система (опыт Республики Татарстан). К., 2000; Социальное обследование лекарственного обеспечения онкологических больных // Фармация. 2001. № 6.

**САФИУ́ЛЛИН** Фаикъ Нәби улы (25.7.1948, Молотов өлкәсенең Октябрь р-ны Казаклар а.), а.х. фән. д-ры (1999), проф. (2000). Пермь а.х. ин-тын тәмамлый. 1966–73 елларда Пермь өлкәсе пр-тиеләрендә эшли. 1977–79 да Пермь өлкәсенең Уинск р-ны Киров исем. к-зында баш агроном. 1979–88 дә Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында өлкән фәнни хезмәткәр. 1988 дән Казан аграр





Р.Т. С а ф и у л л и н. 1. Режиссёр А.Тарковскийның «Сталкер» кинофильмына эскиз. Гуашь, акрил. 1978; 2. «Зөя атау-шәһәре». Киндер. Акрил. 2009.



Ф.Ш. Сафиуллин.



Г.Г. Сафиуллина.

ун-тында җир төзүчелек һәм агроэкология каф. мөдире. Хезмәтләре май культуралары һәм күпьеллык үләннәр үстерү мәсьәләләренә карый. С. ТРның туфрак-климат шартларында рапс, көнбагыш, шепкән, горчица һәм җитен үстерү технологияләрен эшли; бу культуралар респ-каның 500 дән артык хуҗалыгының 55–60 мең *га* мәйданында чәчелә, күрше төбәкләр һәм өлкәләрдә 25–30 мең *га* мәйданда үстерелә (Мари Респ-касы, Пермь өлкәсе, Чуаш Респ-касы). Җитештерүнең икътисади нигезләрен һәм фәнни нигезләнгән технологияләрен эшләгәне, рапсны эшкәртү һәм куллануны гамәлгә керткәне өчен ТР Дәүләт бүләге бирелә (1997). ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Масличные культуры: Производство и переработка. К., 2000 (автордаш); Клевер луговой: на корм и семена. К., 2005 (автордаш).

**САФИУ́ЛЛИН** Фәндәс Шакир улы (17.8.1936, Азнакай р-ны Мәлбагыш а.), сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, полковник (1984). Саратов танк уч-щесен (1957), Белоруссия ун-тының филос. ф-тын (1970) тәмамлый. 1954–88 елларда СССР Кораллы көчләрендә хезмәт итә. 1988–90 да Ракета гаскәрләре Казан югары хәрби командирлар уч-щесенең иҗтимагый фәннәр кафедрасында укыта. 1990–95 тә ТР халык депутаты, ЮС Президиумы әгъзасы, Сугыш, хезмәт ветераннары, инвалидлар һәм шәфкать даими комиссиясе рәисе. 1995–99 да ТР Дәүләт Советы депутаты, «Идел-йорт» депутатлар төркеме җитәкчесе. ТРның Дәүләт суверенлыгы турындагы Декларация (1990) һәм ТР Конституциясе (1992), «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы закон (1992) проектларын эшләү комиссияләре әгъзасы. 1991 дә ТР һәм РФ дәүләт органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турындагы сөйләшүләрдә, РФ һәм ТР рәсми делегацияләре киңәшмәләрендә катнаша. Бөтентатар иҗтимагый үзәге рәис-координаторы (1998), Татар халкын саклап калу һәм үстерү программасын эшләүдә катнаша. 1999–2003 тә РФ Дәүләт Думасы депутаты («Ватаныбыз — бөтен Россия» блогыннан), «Россия регионнары» — «Регионы России» депутатлар төркеме, Халыкара эшләр ком-ты әгъзасы, «Халыклар дуслыгы — Россия бердәмлеге» фракцияара депутатлар төркеме рәистәше. Геосәясәт, Чечен Респ-касындагы хәлләрне сәяси хәл итү Дума комиссияләре эшчәнлегендә катнаша. Мәкаләләре рус булмаган халыкларның (аеруча РФдәге татарларның) хокукларын чикләү, урта белем бирү мәктәпләрендә Россия халыкларының үз балаларын туган телләрендә укыту хокукын чикләү мәсьәләләренә багышлана. «Ватанга СССР Кораллы Көчләрендә хезмәт иткән өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х ә с ә н о в З. Милли каһарман // Мирас. 1996. № 5/6; Т а г и р о в И.Р. История национальной государственности татарского народа и Татарстана. К., 2000.

**САФИУ́ЛЛИН** Юныс Габдулла улы (18.10.1947, Яшел Үзән р-ны Бакырчы а.), драматург, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1996). 1966 елда Казан театр уч-щесен, 1976 да Мәскәү театр сәнгате ин-ты каршындагы Югары режиссёрлык курсларын тәмамлый. 1966 дан Татар респ-ка күчмә театр актёры. 1981–2007 дә Татар акад. театры актёры һәм әдәби бүлек мөдире. С.ның беренче пьесалары постмодернизм үрнәгендә иҗат ителә (куелмаган). «Әллә өйләнергә инде?!» (1978 дә Татар драма һәм комедия театрында куела), «Менә без дә үсеп җитттек», «Ни булган бу ирләргә!?» (1979, 1980 дә Әлмәт татар драма театрында куела), «Ләйсән ире Хәсән»



«Идегәй» спектакленнән күренеш. Туктамыш хан – СССРның халык артисты Ш. Биктимеров, Идегәй — РСФСРның халык артисты Р. Таҗетдинов.

(1986 да Татар акад. театрында куела) комедияләренә социаль юнәлеш хас; «Алмазбулат» (1981 дә Татар акад. театрында куела), «Кыямәт көне» (1985 тә Татар «Әкият» курчак театрында куела), «Серле балдак мажаралары» (2007 дә Казан татар яшь тамашачылар театрында куела) пьесалары мифологик символикага корылган. Әфган сугышы солдатларына багышланган «Пар канат» драмасы (1988 дә Минзәлә татар драма театрында куела) һәм Чечня сугышында катнашучылар тормышыннан алып язылган «Йөзек һәм хәнҗәр» трагедиясе (1997 дә Түбән Кама татар драма театрында куела) дилогия кебек кабул ителәләр. С. иҗатында аеруча яңгыраш тудырган әсәр — «Идегәй» тарихи трагедиясе (1994 тә Татар акад. театрында куела). Мәскәү театр белгечләре дә «Идегәй»не дөнья драматургиясе дәрәҗәсендәге трагедия жанрына җавап бирерлек, сәнгати яктан югары эшләнгән әсәр дип бәялиләр. С. тәрҗемәләре — А.Галинның «Таң йолдызы» 1988 дә Минзәлә татар драма театрында, Г.Хугаевның «Кара чикмән» әсәре 2001 дә Татар акад. театрында куелалар. Тулы метражлы «Зөләйха» (Г.Исхакыйның шул исемдәге пьесасы буенча, 2004) нәфис фильмы сценарие авторы. 2006 да 4 новелладан торган «Акмулла» драмасы Татар акад. театрында куела. 2015 тә Кол Гали поэмасы буенча «Йосыф-Зөләйха» муз. риваяте иҗат итә (2015 тә Башкорт акад. театрында (Уфа) куела). «Чәчәкләр һәм күз яшьләре» (1999) документаль повесте, ш.у. күренекле театр әһелләренә багышланган «Дамир Сираҗиев» (2009), «Рәфкать Бикчәнтәев турында истәлекләр» (2006), «Ринат Таҗетдинов» (2009), «Газиз Айдарский» (2011; рус телендә 2012) истәлек китаплары авторы.

Ә с ә р.: Менә без дә үсеп җиттек. Пьесалар. К., 1983; Пар канат: Пьесалар. К., 1997; Әллә өйләнергә инде?!: Пьесалар. К., 2004.

*Әд.:* Г ы й л ә җ е в А. Ак кеше, пакъ кеше // Казан утлары. 1997. № 10; М и ң н у л л и н а Ф.Х. Юныс Сафиуллин драматургиясе. К., 2007; Ә х м ә д у л л и н А.Г. Күңелләрне уятыр: хәзерге татар драматургиясе. К., 2007; З а к и р җ а н о в Ә.М. Рухи таяныч: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. К., 2011; И г ъ л а м о в Р.М. В пространстве трагедии. Идель. 1998. № 2; С а т т а р о в а А.М. Современная татарская драматургия 1985–2000 гг. К., 2003; П о в а р и с о в С. Кешелеклелек тыузырган могжиза. Башкортстан. 2016, 22 февр.

**САФИУ́ЛЛИНА** Әминә Кәрим кызы (22.7.1925, Арча кантоны Ямаширмә а. — 20.1.2015, Казан), теле- һәм радиожурналист, ТАССР һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1964, 1980). 1941–45 елларда Казанда М.И.Калинин исем. з-дта эшли. 1949 да Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң, ТАССР МС каршындагы Радиофикация ком-тында диктор. 1959 дан Казан телестудиясе эшен оештыруда катнаша, телевидение тапшыруларын, ш.и. «Хатлар укыганда» авторлык программасын алып баручы. 1966–83 тә ТАССР дәүләт радио һәм телевидение ком-тында әдәби-нәфис сүз тапшыруларының баш мөхәррире. 1993–2000 дә Казан татар музыка гимназиясендә укытучы. «Почёт билгесе» ордены (1971), медальләр б-н бүләкләнә.

**САФИУ́ЛЛИНА** Гөлгенә Флүн кызы (9.6.1966, Актаныш р-ны Кәзкәй а.), биолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005), а.х. фән. канд. (2007). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1989), Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында: 1997 дән А.х. биотехнологияләре үзәгенең бәрәңгене микроклональ үрчетү лаб-ясе мөдире. Дәүләт бүләге ТРда сәламәтләндерелгән нигездә бәрәңге орлыкчылыгы системасын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**САФИУ́ЛЛИНА** Гөлзада Гомәр кызы (8.9.1946, Арча р-ны Шекә а.), җырчы, ТРның халык артисты (2001), Кырым Автономияле Респ-касының атказ. сәнгать эшлеклесе (2001). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1970). 1993 елга кадәр Үзбәкстанда белгечлеге бу-



Сәхнәдә Г.Г. Сафиуллина.

енча эшли, бер үк вакытта үзешчән сәнгатьтә катнаша, ш.и. Ташкентта татар «Дуслык» ансамблен оештыра, ансамбль еш кына ТАССР һәм Үзбәкстан ССРның шәһәр һәм торак пунктларында концертлар һәм спектакльләр б-н чыгышлар ясый. 1993–99 да Куйбышев филармониясе солист-вокалисты, концерт программаларын алып баручы. 1980 нән Казанда. Концертлар алып бара һәм иҗтимагый эшчәнлек б-н шөгыльләнә. Россиядә һәм чит илләрдә (Греция, Италия, Франция, Мальта, Кипр, Мисыр, Израиль, Төркия, Һиндстан, АКШ һ.б.) гастрольләрдә йөри, фольклор һәм җыр фестивальләрендә катнаша, радио һәм телевидениедә (ш.и. 200 гә якын фонд язмалары) чыгышлар ясый. Җырчының репертуарын татар халык җырлары (ш.и. бәетләр һәм мөнәҗәтләр), татар композиторларының җырлары тәшкил итә. Аудио- һәм видеодисклар чыгаруны да кертеп, С. татар халкының рухи һәм сәнгати мирасын пропагандалау буенча зур эш алып бара. Балалар һәм яшьләргә муз. тәрбия һәм белем бирүгә күп көч куя. Казанда «Гөлзада» иҗат студиясен, 1999 дан төрки-татар «Сөембикә» балалар иҗаты фестивален булдыруны башлап йөрүче һәм оештыручы. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге лауреаты (1988). «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Ф.Ш.Салитова.*

**САФИУ́ЛЛИНА** Гөлнара Илдус кызы (2.7.1966, Баулы р-ны Бәйрәкә а.), невропатолог, мед. фән. д-ры (2007). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1989), Казан шәһәре йогышлы авырулар клиник хастаханәсендә эшли. 1995 елдан Казан мед. академиясендә, неврология, рефлексотерапия каф. профессоры (2008 дән). Хезмәтләре невропатияләрне дәвалау һәм кисәтүгә, инвалидларны реабилитацияләүнең комплекслы ысулларын эшләүгә карый. ТРның Традицион мед. белгечләре иҗтимагый оешмасы президенты (2008 дән).

Х е з м.: Роль методов комплементарной медицины в оптимизации лечебно-профилактической помощи детям // Общественное здоровье и здравоохранение. К., 2014. № 2 (автордаш).


**САФИУ́ЛЛИНА** Зөлфия Абдулла кызы (14.4.1952, Казан), педагог, библиограф, пед. фән. д-ры (1994), проф. (1997), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2001). 1973 елда Казан мәдәният ин-тын тәмамлый, 1977 дән шунда ук эшли, документларны фәнни эшкәртү каф. мөдире (1994–98 һәм 2003 тән), проректор (1998–2003). Библиография белемендә яңа юнәлеш — китап укучыларның библиографик диагностикасын эшли.

Х е з м.: Текстовая библиотечно-библиографическая диагностика читателей. М., 1994; Информация: ценность и оценка. М., 2006.

**САФИУ́ЛЛИНА** Фәридә Идрис кызы (12.1.1958, Казан), тренер, (инвалидлар арасында чаңгы спорты), ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (1999), Россиянең атказ. тренеры (2003). Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1979). 1979–83 елларда гимнастика буенча өлкән инструктор, 1983–87 дә «Спартак» ирекле спорт җәмгыяте Татарстан респ-ка советының «СССР оборонага һәм хезмәткә әзер бул» сәламәтләндерү бүлеге һәм комплексы мөдире, 1987–93 тә Профсоюзлар Татарстан өлкә Советы — физкультура-спорт җәмгыятенең хезмәт күрсәтү өлкәсендәге эшчеләренең физик тәрбия бүлегендә инструктор. 1993–94 тә инвалидларның «Идел» физкультура-спорт клубында директор, 1994 тән Казанда ТР инвалидлар физкультура спорт җәмгыяте рәисе (бүленеп: 2000–01 дә Яшел Үзән шәһәрендә инвалидларның «Идел» Респ-ка социаль реабилитация үзәгендә дәвалау физкультурасы инструкторы. Шәкертләре арасында — Европа (2001), дөнья (2003, 2005), Паралимпия уеннары (2006) чемпионы И.В.Полякова.



Ф.С. Сафиуллина.



Г.В. Сафонов.



П.С. Сафронов.

**САФИУ́ЛЛИНА** Флёра Садри кызы (24.5.1938, Сарман р-ны Теләнче-Тамак а. — 6.12.2011, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (2001), проф. (1997), ТРның атказ. мәктәп укытучысы (1993), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1960), шунда ук эшли; чит ил студентларына татар теле өйрәтү каф. мөдире (1992–2008). Хезмәтләре татар теле лексикографиясе һәм синтаксисына карый. Югары һәм урта мәктәпләр өчен дәреслекләр һәм уку-укыту ярдәмлекләре, татар телен өйрәнүчеләр өчен сүзлекләр, үзөйрәткечләр һәм сөйләшергә өйрәткечләр авторы.

Х е з м.: Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. К., 1999; Тел гыйлеменә кереш. К., 2001; Антонимнар сүзлеге. К., 2005; Синтаксис татарской разговорной речи. К., 1978; Татарско-русский фразеологический словарь. К., 2001; Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. К., 2007 (автордаш).

*Әд.:* Фәнгә багышланган гомер. К., 2008; Казанская лингвистическая школа. К., 2008.

**САФО́НОВ** Гавриил Васильевич (25.3.1898, Казан губ., Тәтеш өязе Кече Фролово а. — 12.7.1976, Мари Респ-касы, Звенигово р-ны Красногорск пос.), Дан орденының тулы кавалеры (19.3.1944, 17.8.1944, 24.3.1945), гв. старшинасы. Заводта горновщик, аннары колхозда бригадир булып эшли. Гражданнар сугышында катнаша. 1942 елның февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 465 нче укчы полкның сапёрлар взводында отделение командиры (27 нче һәм 1 нче гв. армияләренең 167 нче укчы дивизиясе). Төньяк-Көнбатыш, 1 нче һәм 4 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Демян (1943), Белгород-Харьков (1943), Житомир-Бердичев (1944), Львов-Сандомир (1944) һәм Моравска-Острава (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 10–11 февралендә Виноград һәм Толстые Роги (Черкассы өлкәсе Лысянка р-ны) торак пунктлары янындагы сугышларда батырлык күрсәтә: отделениесе б-н алгы сызыкта төп танк һөҗүме куркынычы булган юнәлештә миналар куеп чыга; С. һөҗүм барышында җимерелгән күперне торгыза, соңыннан ул күпердән пехота һәм танклар узарга тиеш була; 1944 нең 19 июлендә Стрыпа елгасын кичкәндә, С. җитәкчелегендәге отделение күперне төзәтә һәм батальонга икенче ярга чыгуны тәэмин итә; Глинна торак пункты (Тернополь шәһәреннән 30 *км* көнбатыштарак, Украина ССР) янында отделение 12 минаны зарарсызландыра; Днестр елгасына якынлашканда (Галич шәһәреннән төньяк-көнбатыштарак), тимер юл күперен минадан арындыра, уңъяк ярда танкка каршы 185 минаны зарарсызландыра. 1944 нең 23–29 ноябрендә Собранце торак пункты (Гуменне шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Чехословакия) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: С. җитәкчелегендәге сугышчылар киртәләрне үтү өчен юл ясыйлар, укчы подразделениесенә алга үтүне тәэмин итеп, пехотага каршы 81 һәм танкка каршы 52 минаны зарарсызландыралар. С. беренчеләрдән булып торак пунктка бәреп керә һәм, автоматтан атып, дошманның 5 солдатын юк итә; Лесне-Рыковце торак пунктына һөҗүм барышында (Чехословакия) дошманның миналы кырлары аша үзйөрешле артиллерияне озата барып, югалтуларга дучар булмас өчен, танкка каршы 96 һәм пехотага каршы 188 минаны зарарсызландыра. 1945 тә демобилизацияләнгәннән соң, Красногорскида яши. Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**САФО́НОВО** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 10 *км* көнчыгыштарак, Казан–Түбән Новгород автомагистрале буенда. 2010 елда 179 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 68%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 17 йөз башында нигез салына. 17 йөзнең 2 нче яртысыннан *Раифа Богородица пустыне* биләмәсе буларак билгеле, 1763 тә халкы — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, он тарту, күмер яндыру, киндер сугу, таш эшкәртү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.да 2 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 365,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Ильинка волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында, 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юди-

но, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 34 ир-ат; 1859 да — 111, 1897 дә — 181, 1908 дә — 211, 1920 дә — 254, 1926 да — 308, 1938 дә — 297, 1949 да — 150, 1958 дә — 234, 1970 тә — 258, 1979 да — 307, 1989 да — 267, 2002 дә — 186 кеше.

**САФРО́НОВ** Николай Николаевич (23.10.1945, Ленинград), кою технологияләре өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2001), проф. (2004). 1970 елда Ленинград политехник ин-тын тәмамлый. Донецк политехник (1976–82), Брянск а.х. (1982–84) ин-тларында, Брянск ярымүткәргеч приборлар з-дында (1984–86) эшли. 1986 дан Кама инженерлык-икътисад академиясендә (хәзер Казан ун-тының Чаллы ин-ты, Чаллы ш.), кою производствосы машиналары һәм технологияләре каф. профессоры (2002 дән), электр энергетикасы һәм электр техникасы каф. профессоры (2012 дән). Хезмәтләре тимерле дисперс калдыкларны үтилләштерүгә карый. С. даими токта турыдан-туры электр дугасыннан җылытыла һәм металл фазасы катодта полярлаша торган махсус кою агрегатының технол. критериаль модельләрен эшли. Уйлап табуга 13 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Оптимизация инженерных задач планированием эксперимента. Наб. Челны, 2002 (автордаш); Ваграночный процесс на комбинированном дутье с дисперсными промышленными отходами. Наб. Челны, 2004; Утилизация дисперсных промышленных отходов в ваграночном процессе. СПб., 2004 (автордаш).

**САФРО́НОВ** Пётр Сергеевич (1.1.1925, Алабуга кантоны Моркваши а. — ноябрь, 1995, Коми Респ-касы Сыктывкар ш.), Сов. Союзы Герое (15.1.1944), гв. подполковнигы. 1939 елда ФЗӨ мәктәбен тәмамлый, Бондюг посёлогына (хәзер Менделеев ш.) эшкә килә. 1943 нең гыйнварыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 234 нче гв. укчы полкында укчы (61 нче армиянең 76 нчы укчы дивизиясе). Үзәк, 3 нче Балтыйк буе һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Чернигов-Припять, Гомель-Речица (икесе дә — 1943), Белоруссия, Рига (икесе дә — 1944) һәм Варашава-Познань (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Мысы авылы (Украина ССРның Чернигов өлкәсе Репкин р-ны) янында Днепр елгасын кичеп чыкканда батырлык күрсәтә: 1943 нең 28 сентябрь төнендә сугышчылар төркеме б-н бергә елганы кичеп, плацдармны басып ала, дошманның берничә контрһөҗүмен кире кайтаруда катнаша, үзе дошманның 10 солдатын юк итә. Сугыштан соң армиядә хезмәтен дәвам итә. 1948 дә демобилизацияләнә. 1963 тән шәһәр тибындагы Железнодорожный посёлогында (Коми АССРның Княжпогост р-ны) Эчке эшләр министрлыгы органнарында эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә. Алабуга шәһәрендә Геройга бюст куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**САФУА́НОВ** Илдар Суфиян улы (28.12.1954, Казан), педагог, математика белгече, физика-матем. фән. канд. (1984), пед. фән. д-ры (2001), проф. (2002). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1977). 1982 елдан Башкорт пед. ин-тының алгебра һәм геом. кафедрасында эшли (Уфа ш.). 1991 дән Чаллы пед. ин-тында математика һәм аны укыту методикасы кафедрасында (1993 тән), каф. мөдире (1993 тән), проректор (2001–07). 2008 дән Мәскәү шәһәр пед. ун-тының алгебра, геом. һәм аларны укыту методикасы каф. мөдире. Хезмәтләре универсаль алгебралар теориясенә, категорияләр теориясенә, югары уку йортларында математика укыту методикасына карый. Аффин модульләр категорияләрен аңлата, югары уку йортларында матем. фәннәрен укытуга генетик яктан якын килү мәсьәләләре чишелешен эшли.

Х е з м.: Алгебра һәм саннар теориясе. Чаллы, 1999; Теория и практика преподавания математических дисциплин в педагогических институтах. Уфа, 1999; The genetic approach to the teaching of Algebra at the universities // International journal of Mathematical Education in Science and Technology. 2005. V. 36.

**САФУА́НОВ** Суфиян Гаяз улы (2.10.1931, БАССРның Туймазы р-ны Бикмәт а. — 30.11.2009, шунда ук), әдәбият галиме, әдәби тәнкыйтьче, филол. фән. канд. (1962), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1981). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1954). Уфада яши. 1957–94 елларда СССР ФАнең Башкортстан ф-лы Тарих, тел һәм әдәбият ин-тында, 1994 тән «Тулпар» ж-лында, 1996–2005 тә Башкортстан пед. ун-тында (1997 дән проф., 1997–2003 тә татар теле һәм әдәбияты каф. мөдире). Эзләнүләре татар, башкорт прозасы, әдәбиятлар багланышларына карый. И.Гази, Ә.Карнай, Г.Хәйри, Һ.Такташ, М.Җәлил, Х.Туфан, М.Әмир, Ә.Еники иҗатларына багышланган хезмәтләр авторы. Алты томлы «Башҡорт совет әҙәбиәте тарихы»ның мәкаләләре авторы (1–6 т., Уфа, 1990–96).

Х е з м.: Рухи күперләр. Өфө, 2005; Межнациональные связи башкирской литературы. М., 1979; Башҡорт балалар әҙәбиәтенең үҫеш проблемалары. Өфө, 1988.

*Әд.:* Н у р у л л и н И. Онытылмас еллар шаһите // Реализм турында мәкаләләр. К., 1974; И с л а м о в Ф. С.Сафуанов — тугандаш әдәбиятлар хадиме // Мәгърифәт, әдәбият һәм тарих сукмаклары буйлап. К., 2002.

**САФЬЯ́Н** (фарсы. سختيان), юка, йомшак, гадәттә, ачык төсләргә буялган, үсемлек төнәтмәсендә дупланган күн. Кәҗә һәм сарык тиресеннән эшләнә. Югары сыйфатлы С. Идел буе Болгар дәүләтендә һәм Казан ханлыгында җитештерелгән. С.ны Казанда җитештерүнең билгеле алымы: башта күнне арыш куасында (100 тирегә 400 *кг* чамасы он) әчетәләр, аннары бал эретелгән суда тоталар, аннан соң имән, тал яки кара чикләвек кайрысы төнәтмәсендә илиләр. Аяк киеме (к. *Башмак, Читек*), галантерия әйберләре, җиһазлар тышлыгы һ.б.ны эшләү өчен кулланыла. 18 йөздә — 20 йөз башында күн җитештерү алга киткән чорда киң таралыш ала.

*Әд.:* Г л у х о в М.С. Не молот железо куёт. К., 1969; Г у л о в а Ф.Ф. Татарская национальная обувь (искусство кожаной мозаики). К., 1985.

**«САФЬЯ́Н»**, табигый күн җитештерүче пр-тие, Татарстандагы борынгы пр-тиеләрнең берсе. Казанда урнашкан. Эшләүчеләр саны — 150 дән артык кеше (2014). 19 йөз башында күн з-ды буларак сәүдәгәр П.И.Котелов тарафыннан нигез салына. 1859 елда «Казанның пайдагы күн заводы ширкәте» милкенә күчә, 1871 дә И.И.*Алафузов* тарафыннан сатып алына һәм *Алафузовларның завод-фабрикалар һәм җитештерү-сәүдә ширкәте* составына кертелә. Национализацияләнгәннән соң (1918) — 1 нче Казан дәүләт күн з-ды, 1959 дан Казан күн комб-ты, 1965 тән составына «Кызыл күнче» хром з-ды (1904 тә А.Жулин нигезли) һәм чималны беренчел эшкәртү з-ды (1932 дә нигезләнә) кергән Казан күн җитештерү берләшмәсе; 1922–96 да В.И.Ленин исемендә, 1996 дан «С.» АҖ.

Башта заводта Кытайга сату өчен өлешчә кул хезмәте б-н кәҗә тиреләреннән *сафьян* әзерләнә, 1840 та юфть, полувал һәм олтан күне эшләү башлана. 1859–73 тә кул хезмәтен механикалаштыруга керешелә: пар б-н эшләүче җиһазлар, көлләү һәм иләү чаннары, әйләнә торган баркалар, механик юдыру барабаннары, иләү, суырту, ышкылау һәм чимал әзерләү аппаратлары һ.б. урнаштырыла, су б-н тәэмин итү системасы куела. Кыйммәтле иләү материаллары (йомырка сарысы, терлек майлары) урынына тал кайрысы кулланыла башлый. 1812–73 тә эшләүчеләр саны (14 тән 550 кешегә кадәр) һәм җитештерү күләме (6 меңнән 1,35 млн. сумлык 185 мең күнгә кадәр) арта; 1897 дә өч катлы җитештерү корпусы төзелә. Казан губернасында күн җитештерүнең гомуми күләмендә завод өлешенә 35% тан (1870 еллар) 50% ка кадәр (1890 еллар) туры килә. Складлар Казан, С.-Петербург, Мәскәү, Ростов-Дон, Одесса, Кавказда урнаша, продукция Германия, Австро-Венгрия, Италия, Төркия, Мисыр, Персиягә җибәрелә. Эшләнмәләр Парижда (1867), Лондонда (1874) һ.б. җирләрдә халыкара күргәзмәләрдә бүләкләргә лаек була. Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышлары чорында пр-тие казна заказларын башкара. 1 нче бишьеллыкта (1929–32) иләү экстратларын һәм химик материаллар эшләү җайга салына, җитештерү куәтләре арттырыла, технол. процесс вакыты кыскартыла; җитештерү күләме 6 тапкыр арта. Бөек Ватан сугышы чорында пр-тие Мәскәү өлкәсенең Клинцы шәһәреннән эвакуацияләнгән «Красный гигант» з-ды б-н берләштерелә һәм хәрби ихтыяҗлар өчен күн эшләү буенча специальләшә. 1960 елларда тамырдан үзгәртеп кору барышында искергән җиһазлар урынына 600 берәмлек чамасы заманча җиһазлар урнаштырыла. Көлләү һәм иләү өчен әйләнмә барабанлы аппаратура, дымны сыгып чыгару, күнне өлгеләү һәм кысу, басып бизәк төшерү, чемодан формалары ясау өчен конвейерлы һәм ярымавтомат линияләр, транспортлау механизмнары һәм пресслар, чүкеп беркетү станоклары һәм тегү машиналары, күн мәйданын исәпләү өчен электрон машиналар файдаланута кертелү, ш.у. җиңел актив матдәләр, синтетик майлар һәм иләү экстрактлары куллану нәтиҗәсендә, җитештерү мәйданнарын киңәйтмичә генә технол. циклны берничә тапкыр кыскартуга, продукция сыйфатын яхшыртуга, күн җитештерүне 1940 та

43 млн. *дм*² дан 1965 тә 101,1 млн. *дм*² га кадәр арттыруга ирешелә. Бу чорда 20 ләп төрдә юфть һәм олтан күннәре, 40 төрдә күн-галантерея эшләнмәләре (ш.и. оптик приборлар һәм радиоалгычлар өчен тышлыклар, каешлар, чемодан, букча, рюкзаклар, футбол туплары, автомобильләр өчен эшләнмәләр), ш.у. күчергеч каешлар, прокладка, манжетлар һәм илдә тиңе булмаган башка техник детальләр эшләп чыгарыла. Җитештерү калдыкларын эшкәртү, мездрадан җилем ясау үзләштерелә. Продукция СССРның күпчелек төбәкләренә җибәрелә, Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европа, Азия, Африка илләренә чыгарыла.

1970–80 елларда яңа корпуслар, химия станциясе төзелә, Италия, Германия, Югославия, Чехословакиядән кайтарылган җиһазлар җирлегендә пр-тиене алга таба яңартып техник коралландыру дәвам итә (вакуумлы киптерү җайланмалары, сыгу, ышкылау һәм тарттыру-йомшарту машиналары урнаштырыла), комплекслы механикалаштырылган цехлар оештырыла. 1990 елга берләшмәдә 2200 ләп кеше эшли, бу чорда күн товарлар житештерү күрсәткечләре (млн. *дм*²): хром әйберләр — 148,4, юфть — 76,2, каты күн — 64,4; 16,3 млн. сумлык күн галантерея эшләнмәләре житештерелә. 2000 еллар башында чит илләрдән китерелгән химик реагентлар кулланып заманча эшкәртү технологияләре гамәлгә кертелә башлый. Даими рәвештә төрле төстәге һәм өслекле күннәрнең ассортименты баетыла. Чимал (мөгезле эре терлек тиреләре), башлыча, Татарстан ит комб-тларыннан алына. 2011 дә эшләп чыгарылган күн товарлар (млн. *дм*²): хром әйберләр — 32,3, «Вет-Блю» ярымфабрикаты — 0,8, каты күн эшләнмәләр — 0,05, юфть — 0,03, чи каеш — 0,003; 0,5 млн. сумлык күн-галантерея эшләнмәләре җитештерелә. Продукция РФнең аяк киемнәре җитештерү һәм күн-галантерея сәнәгате пр-тиеләренә (алар арасында Казандагы «*Спартак*», «*Күн галантерея фирмасы*» акц. җәмгыятьләре) җибәрелә, аның 40% тан күбрәк өлеше якын чит илләргә чыгарыла. Пр-тиенең күп кенә эшчеләре дәүләт бүләкләренә лаек була.

Пр-тие җитәкчеләре арасында: Г.Ф.Панькин, И.Я.Эйдлин, А.М.Тлюстангелов, В.Г.Соловьёв, Д.А.Алиев, Р.Р.Рузыев (2014 тән).

*Әд.:* Т р у ф у с М.А. Кожевенная промышленность Казанского края. К., 1928; Из опыта работы Казанского кожевенного комбината имени В.И.Ленина. М., 1970. *С.Г.Белов.*

**САХА́ЕВ** Исхак Идрис улы (20.8.1930, Оренбург өлкәсенең Әсәкәй р-ны Рамазановка пос.), математик, физика-матем. фән. д-ры (1995), проф. (1999). Богырыслан укытучылар ин-тын тәмамлый (1950). 1953–57 елларда Казан ун-тында укый, 1959 да Берлин ун-тын тәмамлый. 1959 дан Казан ун-тында эшли, алгебра каф. профессоры (1999 дан). Хезмәтләре алгебралар, боҗралар, модульләргә карый. Чикләнгән яссы модульләрнең проективлык критериен билгели. Медаль б-н бүләкләнә. Алгебраик боҗраларның мөһим классы С. исеме б-н аталган (2006).

Х е з м.: О проективности конечно-порождённых плоских модулей // Сиб. мат. журн. 1965. № 6; О конечной порождённости проективных модулей // Изв. вузов. Математика. 1977. № 9; О SBI-кольцах и гипотезе Лазара // Mathematische Nachrichten. 1987. V.130.

**СА́ХАРОВКА** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 12 *км* көнчыгыштарак, Шонталы елгасы буенда. 2010 елда 404 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новосёлки исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстиянннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Христо-Рождество чиркәве (2000 еллар башында шул исемдәге яңа чиркәү төзелә), укыргa-язарга өйрәтү мәктәбе (1886 да ачыла), тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 936 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Кызылъяр волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 22 ир-ат; 1859 да — 474, 1897 дә — 817, 1908 дә — 1003, 1920 дә — 1097, 1926 да — 1123, 1938 дә — 849, 1949 да — 588, 1958 дә — 580, 1970 тә — 719, 1979 да — 505, 1989 да — 429, 2002 дә — 447 кеше.

**САЧЕНКО́В** Александр Васильевич (11.9.1928, Мордва АССРның Атяшево р-ны Зур Манадыш а. — 8.5.1988, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1965), проф. (1966), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1987). 1951 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1950–56 да СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында эшли. 1956–88 дә Казан ун-тында, теоретик механика каф. мөдире (1979 дан), бер үк вакытта, 1964 тән, Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында. Хезмәтләре юка тышчалы конструкцияләрнең ныклыгына, тотрыклылыгына һәм тирбәнүләренә карый. С. пластина һәм сүрүләрнең сыгылмалылык чикләрендә һәм бу чикләрдән тыш, сыгылмалы системаларның тирбәнүләр һәм динамик тотрыклылыгы өлкәсендәге тотрыклылыгын исәпли. Күп катламлы сүрүләр теориясен үстерә, пластиналар һәм сүрүләр теориясенең — нәсызыкча, эластиклык һәм пластиклык теориясенең фәзаи мәсьәләләрен чишүнең нәтиҗәле алымнарын эшли. С.ның күп кенә фәнни хезмәтләре релятивистик механикага карый. Пластина һәм сүрүләр механикасында теоретик-эксперименталь тикшеренүләр алымының авторы.

Х е з м.: Теория оболочек с учётом поперечного сдвига. К., 1978 (автордаш); К вариационным уравнениям смешанного типа в теории упругости // Изв. вузов. Математика. 1980. № 5 (автордаш); Изгиб цилиндрических оболочек и плит с учётом поперечной деформации // Изв. вузов. Математика. 1981. № 11 (автордаш).

**САЯ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Сола елгасының (Казансу елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 22,5 *км*, бассейнының мәйданы 120 *км*². Биектау р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Кече Рәс авылыннан төньяктарак, тамагы Тимофеевка авылыннан 1 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 70 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 8%. С.ның 1 *км* дан 6,1 *км* га кадәр озынлыктагы 13 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,61 *км/км*². Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 136 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,175 *м*³/*с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л* дан артык. С. бассейнында суының күләме 1,2 млн. *м*³ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**САЯ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 17 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сая елгасы буенда. 2010 елда 397 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек, умартачылык. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1602–03 тән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.да мәчет (1896 да төзелә), мәктәп, тимерчелек, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1867,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Салкын Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 115 ир-ат; 1859 да — 850, 1897 дә — 1127, 1908 дә — 1182, 1920 дә — 1069, 1926 да — 1219, 1938 дә — 999, 1949 да — 794, 1958 дә — 675, 1970 тә — 623, 1989 да — 392, 2002 дә — 387 кеше.

**САЯ́ПОВА** Альбина Мазһар кызы (17.2.1948, БАССРның Яңавыл р-ны Яңавыл пос.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1999), проф. (2002). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1973), Казанда урта мәктәптә укыта. 1978 елдан СССР Педагогика ФАнең Һөнәри-техник фәнни-тикшеренү ин-тында, 1985 тән Татар гуманитар-пед. ун-тында (2003–08 дә рус һәм чит илләр әдәбияты һәм аларны укыту методикасы каф. мөдире), 2012 дән Казан ун-тында укыта. Хезмәтләре рус әдәбияты тарихы, татар-рус әдәбиятлары багланышларына карый.

Х е з м.: Поэзия Дардменда и символизм. К., 1997; Читая Чехова. К., 2003.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**СӘВӘЛӘ́Й** елгасы, Көнчыгыш Кама арьягында, Дала Зәенең сул кушылдыгы. Озынлыгы 9,3 *км*, бассейнының мәйданы 22,6 *км*². Зәй р-ны терр-ясендә ага. Елга башы Сәвәләй авылыннан 6 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Утяшкино авылыннан 2 *км* көньякта-

рак. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 75 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 86 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,02 *м*³/*с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 12–20 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан артык.

**СӘВӘЛӘ́Й** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 24 *км* көньяктарак, Сәвәләй елгасы буенда. 2010 елда 964 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, олаучылык, киез итек басу, чыпта сугу, тәгәрмәч, арба һәм чана ясау б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышында* Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында С.дә Троица чиркәве (1889 да изгеләшә), миссионерлык мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1570 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Акташ волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 528, 1897 дә — 1169, 1913 тә — 1260, 1920 дә — 1298, 1926 да — 1171, 1938 дә — 1119, 1949 да — 971, 1958 дә — 1115, 1970 тә — 1235, 1979 да — 962, 1989 да — 849, 2002 дә — 943 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**СӘВЕКЛЕ́** фермасы посёлогы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 14 *км* төньяк-көнбатыштарак, Игәнә елгасыннан 1 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 19 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көненнән Сарман р-нында. Халык саны: 1938 дә — 104, 1949 да — 112, 1958 дә — 100, 1970 тә — 110, 1979 да — 85, 1989 да — 19, 2002 дә — 22 кеше.

**СӘГАДИ́ЕВ** Владимир Ильяс улы (21.4.1939, Бөгелмә — 7.8.2003, Казан), җылылык техникасы өлкәсендәге галим, техник фән. д-ры (1990), проф. (1991), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995). 1963 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, «Теплоконтроль» з-дында (Казан) эшли. 1965 тән Казан авиация ин-тының махсус двигательләр кафедрасында. 1972 дән Казан архит-ра-төзелеш ун-тында, проф. (1990–92), җылылык техникасы каф. мөдире (1993–2003). Хезмәтләре сәнәгый җылылык энергетикасы җиһазларында дисперс системаларның радиацион үзлекләрен өйрәнүгә карый. С. газ-тузан агымының интеграль һәм монохроматик нурландыру сәләте аның химик һәм минераль составына, тузанлану дәрәҗәсенә, темп-расына һәм кисәкчекләрнең дисперслылыгына бәйлелеген ачыклый; ТЭЦларның пар казаннарында тузанлы күмер яккында нурланыш энергиясе күчеше закончалыкларын билгели; минераль һәм химик составлының чыгып, оптик шома өслекле күп компонентлы нәорганик материалның монохроматик чагылдыру сәләтен билгеләү методикасын эшли. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Монохроматическая отражательная способность неорганических порошкообразных материалов // Инженерно-физ. журн. 1990. Т. 58, № 1; Радиационные характеристики сложных неорганических материалов с оптически гладкой поверхностью // Инженерно-физ. журн. 1990. Т. 58, № 2; Расчёт теплот сгорания углеводородов гомологического ряда метана // Инженерно-физ. журн. 2002. Т. 75, № 3 (автордаш).

**СӘГАДИ́ЕВ** Евгений Владимирович (1.8.1970, Казан), физик-химик, химия фән. д-ры (2007). 1992 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1994–97 дә, 2000–02 дә Казан архит-ра-төзелеш академиясендә эшли. 1997–99 да һәм 2002 дән Казан технол. ун-тында, гомуми химик технол. каф. профессоры (2007 дән). Хезмәтләре термохимиягә карый. С. органик һәм элементорганик кушылмаларның төрле классларының термохимик характеристикаларын (эрү энтальпиясе, сольватлашу, пар ясалу, хасил булу һәм яну) билгели һәм аларны кушылмаларның химик структурасы б-н чагыштырып карау мөмкинлеген күрсәтә. Пар ясалу энтальпиясен кайнау темп-расы б-н һәм кайнау темп-расын моляр рефракция б-н бәйли торган эмпирик тигезләмәләр тәкъдим итә. Органик кушылмаларның төп термохимик характеристикалары б-н моляр күләмнәре арасындагы бәйлелекне ачыклый.

Х е з м.: Расчёт теплот сгорания предельных углеводородов, входящих в энергетические топлива // Теплофизика высоких температур. 2004. Т. 40, № 4 (автордаш); Расчёт и экспериментальное определение термохимических характеристик органических соединений: Новый справ. химика и технолога. СПб., 2006. Т. 12 (автордаш); Calculations of the enthalpies of combustion of organic compounds by the additive scheme // Russian Journal of Physical Chemistry. 2006. V. 80 (Supplement № 1) (автордаш).

**СӘГЪДЕТДИ́Н** Сәйдәш угылы Нурлати (19 йөз), шагыйрь. Музыканың туум һәм аның гаҗәеп матурлыгы турында хикәяләүче (суфичылык әдәбияты традицияләрендә) «Әбъйату мәгарифе калбийат» («Күңелне пакьләндерүче шигырьләр», 1846) дидактик поэмасы авторы. 18 йөз ахырында Ош шәһәре янында яшәгән шагыйрь Хувайданың «Рәхәти дил» («Күңел рәхәтлеге») хезмәте дә кергән кулъязма җыентыкта теркәлгән. Кулъязмада С. поэма авторы итеп күрсәтелгән.

*М.В.Гайнетдинов.*

**СӘГЪДИ́** (фарсы سعدى; тәхәллүсе, тулы исеме Мөслахеддин Әбү-Мөхәммәд Габдулла Сәгъди Ширази) (1203–1210 арасы, Иран, Шираз ш. — 9.12.1292, шунда ук), фарсы шагыйре, фарсы һәм таҗик әдәбиятлары классигы. Фарсы һәм гарәп телләрендә яза. Тәхәллүсе Сәгъди ибне Зәңги (1195–1226 елларда хакимлек итә) исеме б-н бәйле. Аның ярдәме б-н С. Багдадтагы «Низамия» мәдрәсәсенә укырга керә. 1220 еллар уртасыннан Шәрекъ илләренә сәяхәт кыла, Мәккәгә хаҗга бара, дини-әхлакый вәгазьләр б-н чыгышлар ясый. Берничә елдан Ширазга кайта һәм гомеренең ахырына кадәр шунда ялгыз яши. С.нең «Бостан» («Җимеш бакчасы», 1257) фәлсәфи поэмасы камил хаким нинди булырга тиеш дигән фикерне чагылдырган гыйбрәтле хикәяләрне, уйлануларны үз эченә ала. Шагыйрь хакимнәрне гади кешеләргә карата кешелекле булырга өнди, гаскәр башлыклары һәм түрәләрнең гадел булырга тиешлеген искәртә, юкса хакимнең киң күңеллелеге һәм игелеклелеге зыян гына китерергә мөмкин ди. «Гөлстан» («Гөл бакчасы», 1258) исемле чәчмә һәм тезмә формада язылган гыйбрәтле хикәяләр китабы патшалар тормышы һәм дәрвишләр холкы, эндәшмәүнең һәм аздан да канәгать булуның өстенлеге, мәхәббәт һәм яшьлек, тәрбия һәм аралашу кагыйдәләре турында сөйли. Китап юмор б-н сугарылган, аның төп идеясе — җәмгыятьтә яшәү нигезе буларак зирәклек һәм аек акылны мактау. Ике әсәр дә Шираз хакиме Әбү Бәкер ибне Сәгъдигә багышланган. Аларда авторның тормыш вакыйгалары һәм маҗаралары, аның сәяхәтләре һәм күзәтүләре тасвирлана. С. ш.у. лирик шигырьләр яза, «Пәнднамә» («Нәсыйхәтләр китабы») исемле чәчмә трактат авторы дип тә фаразлана. С. әсәрләре татар зыялылары, шәкертләр арасында киң таралыш алган, мәдрәсәләрдә фарсы телен өйрәнгәндә кулланма итеп файдаланылган, алар нигезендә төрки-татар телендә назыйрәләр язылган. «Гөлстан» С.Сараи тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителә («Гөлестан бит-төрки», 1391). Мөхәммәд Сәет Җәләл (1915) һ.б.ның тәрҗемәләре дә мәгълүм.

Ә с ә р.: Избранное. Душ., 1954.

*Әд.:* Х о л м о г о р о в М. Шейх Мослихутдин Саади Ширазский и его значение в истории персидской литературы. К., 1865; Гулистан: Критический текст. М., 1959; М и н н е г у л о в Х. Татарская литература и Восточная классика. К., 1993.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**СӘГЪДИ́** (Сәгъдиев) Габдрахман Гайнан улы (26.3.1889, Уфа губ., Златоуст өязе Таймый а. — 6.11.1956, Үзбәкстан ССР, Сәмәрканд ш.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1949). 1902–06 елларда «Рәсүлия» мәдрәсәсендә (Троицк ш.), 1908–11 дә Истанбул ун-тында укый. 1917 гә кадәр укыта. 1918–21 елларда татар-башкорт пед. курсларында (Бөгелмә ш.), 1921–25 тә Үзбәкстан ирләр һәм хатын-кызлар мәгариф ин-тларында, Урта Азия ун-тында (Ташкент ш.), 1925–30 да Татар Коммунистлар ун-тында һәм Казан Көнчыгыш пед. ин-тында (1929 дан проф.) укыта. 1930 дан кабат Урта Азиядә. 1930–32, 1937–41, 1952–56 да Үзбәкстан пед. академиясендә (Сәмәрканд ш.), 1932–37 дә Ташкент пед. ин-тында, 1941–52 дә Урта Азия ун-тында укыта. С. татар, үзбәк, казакъ, төрекмән телләрендә бай әдәби мирас калдыра. Әдәбият тарихын синхрон һәм диахрон аспектларда өйрәнә. «Татар әдәбияты тарихы» (1926) хезмәтендә әдәби процессны тел, иҗ-

тимагый фикер, мәгариф, дин, фән үсеше контекстында карый. «Символизм турында» (М., 1932) китабында «ысул-агым-мәктәп» системасында әдәбият күренешләрен танып белү һәм бәяләү методологиясенең зарурилыгын теоретик яктан дәлилли. Әдәбият теориясе, татар теле морфологиясе һәм синтаксисы, педагогика һәм татар әдәбиятын укыту методикасы тарихы, үзбәк, төрекмән һәм башкорт әдәбиятлары тарихы, шәрекъ педагогикасы буенча дәреслекләр авторы. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Әдәбият дәресләре. Таш., 1925; Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсеше. К., 1926; Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты. К., 1930.

*Әд.:* Габдрахман Сәгъди: Фәнни-биогр. җыентык. К., 2008. *Д.Ф.Заһидуллина.*

**СӘГЪДИ́** Эльвира Фоат кызы (2.1.1952, Ташкент), спортчы, тренер (спорт гимнастикасы), СССРның атказ. спорт остасы (1976), РСФСРның атказ. тренеры (1991). Үзбәкстан физкультура ин-тын тәмамлый (Ташкент, 1974). «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Ташкент, тренеры — В.Ф.Аксёнов). СССР (1972, ирекле күнегүләр, бүрәнә; 1973, бүрәнә; 1974, абс.), дөнья (1974), Олимпия уеннары (1972, 1976, команда беренчелеге) чемпионы; СССР кубогы иясе (1975, күптөр ярыш). СССР (1974, көмеш, бүрәнә; 1973–75, көмеш, ирекле күнегүләр; 1975, бронза, бүрәнә), дөнья (1974, бронза, ирекле күнегүләр) чемпионатлары; СССР (1974, бронза; күптөр ярыш), дөнья (1975, көмеш; этелеп сикерү; бронза, күптөр ярыш — брус, бүрәнә, ирекле күнегүләр) кубоклары призёры. 1974 елдан «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә (Мәскәү) тренер-укытучы. Халыклар дуслыгы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. 1991 дән Канадада яши.

**СӘГЪДИ́ЕВ** Зөфәр Вәзил улы (15.2.1959, Казан), тренер (самбо), Россиянең атказ. тренеры (1993). Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1984). 1984 елдан тренер-укытучы (1984 тән Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбенең «Синтез» СКнда, 1985 тән Респ-ка олимпия резервы «Батыр» махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә, Казан). Шәкертләре арасында — В.А.*Волков*.

**СӘГЪДИ́ЕВ** Ногман Дәрзаман улы (1914, Красноярск краеның хәзерге Ужурск р-ны Кызыл Күл а. — 22.11.1968, шунда ук), а.х. җитештерүен оештыручы, Соц. Хезмәт Герое (1948). 1928–68 елларда Ужурск р-нында: бригадир (1930 дан), «Кызыл күл» (1938–41, 1962–68), К.Маркс исем. (1946–51), 17 нче партсъезд исем. (1951–58) к-злар рәисе; «Малоимышский» с-з бүлегендә идарәче (1958 дән). Герой исеме бөртекле культуралардан югары уңыш алганы өчен бирелә (1947 дә 53 *га* мәйданда 1 *га* дан 32 *ц* бодай). Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз, 1 нче дәрәҗә Дан орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**СӘГЪДИ́ЕВ** Равил Әкрам улы (4.1.1934, Норлат р-ны Айдар а.), журналист, тәрҗемәче, ТАССР һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1984, 1988). Казан пед. ин-тын (1955), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1969) тәмамлый. 1956 елда Курган өлкәсенең Кара-Су авылы урта мәктәбендә укытучы, 1957 дә Удмурт АССРның Починки авылында мәктәп директоры. 1960 тан Казанда «Ватаным Татарстан» г-тасында эшли, 1973 тән мөхәррир урынбасары. ТРның иҗтимагый-сәяси, икътисади, мәдәни тормышы турындагы язмалар, мәкаләләр авторы. 2004–06 да «Научный Татарстан» ж-лында тәрҗемәче. Сәяси әдәбият, публицистика әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. РСФСР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.


**СӘГЪДИ́ЕВ** Рәдиф Нәҗип улы (17.7.1957, Казан), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2005). Казан театр уч-щесен (1981), Казан ун-тын (1993) тәмамлый. Хезмәт биографиясен 1981 елда Әлмәт татар драма театры актёры буларак башлый. 1984 тән Татар драма һәм комедия театрында: актёр, гастрольләр оештыру буенча менеджер (1989 дан). 1998 дән Казан татар яшь тамашачылар театры менеджеры. 2000–05 тә ТР Язучылар берлегендә матур әдәбиятны пропагандалау бүлеге җитәкчесе. 2007 дән Татар драма һәм комедия театрында җәмәгатьчелек б-н элемтәләр буенча директор урынбасары. «Финляндиядә рәхәт, ди» драмасы (1989 да Чаллы татар драма театрында куела), «Сынган беләзек» мелодрамасы (1996 да Татар драма һәм комедия театрында куела), «Яз галәмәте» комедиясе (1998 дә шунда ук куела), балалар өчен «Гүзәл Аппаксылу» пьесасы (2001 дә Казан татар яшь тамашачылар театрында куела), «Ирләр яуга киткәндә» тарихи драмасы (2003), «Канга буялган алтыннар» (1990) һәм «Каргыш» (1992) детектив повестьлары, «Ике кояшлы дөнья» (2002) фантастик һәм «Ирдәүкәләр» (2008) тарихи-мавыктыргыч романнары авторы. ТР Язучылар берлегенең Ф.Хөсни исем. (2011) һәм Д.Сираҗиев (2012) исем. театраль бүләкләр лауреаты.

Ә с ә р: Гүзәл Аппаксылу. К., 2013.

*Әд.:* З ә й д у л л а Р. Җан хөрлеге // Мәдәни җомга. 2007. 20 июнь; Г а й н у л л и н а И. Артистлыктан язучылыкка // Сәхнә. 2007. Сент.-окт.

**СӘГЪДИ́ЕВ** Рәшит Билал улы (13.10.1939, Казан), терапевт, мед. фән. д-ры (1974), проф. (1996). ТАССРның атказ. физик культура һәм спорт хезмәткәре (1990). 1961 елда Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1968), шунда ук эшли, 1971 дән физик тәрбия һәм дәвалау физкультурасы каф. мөдире. Хезмәтләре студентларның хәрәкәт активлыгын һәм физик хезмәткә сәләтлелеген, сәламәтлекне ныгыту өчен йөгерү һәм җәяү йөрү б-н шөгыльләнүчеләрнең физик халәтен; Казан мед. ун-ты студентлары мисалында авырып китү очраклары һәм физик хәрәкәт җитешмәү арасындагы бәйлелекне өйрәнүгә карый. Спорт гимнастикасы буенча СССРның спорт остасы (1960).

Х е з м.: Использование средств восстановления и повышения физической работоспособности после физических нагрузок. К., 1989 (автордаш); Основы теоретического и практического курсов физической культуры. К., 1995; Физическая культура. К., 2000.



Ренад З. Сәгъдиев.

**СӘГЪДИ́ЕВ** Ренад Зиннур улы (13.12. 1941, Казан), химик-физик, химия фән. д-ры (1978), РФА академигы (1997; 1987 елдан СССР ФА мөхбир әгъзасы), ТР ФАнең шәрәфле академигы (2007). Новосибирск ун-тын тәмамлый (1965). РФАнең Себер бүлегендә эшли (Новосибирск ш.): 1965–93 елларда Химик кинетика һәм яну ин-тында, магнит күренешләре лаб-ясе мөдире (1978–83), директор урынбасары (1983 тән); 1993 тән химиядә магнит күренешләрен тикшерү өчен «Халыкара томографик үзәк» ин-тын оештыра һәм аның директоры; бер үк вакытта, 2000 нән, РФАнең Себер бүлеге рәисе урынбасары, 1нче урынбасары. Хезмәтләре химиядә магнит резонансы алымнарын үстерүгә, химик реакцияләрдә магнит-спин эффектларына, ТМР-томографиягә карый. С. күп спинлы системаларга, аерым алганда, электрон-алмашу тәэсир итешүләренең үзенчәлекләренә фундаменталь тикшерүләр үткәрә. Рекордлы магнит характеристикаларына ия булган түбән темп-ралы ферромагнетикларның яңа тибын булдыра. Төшләрнең химик поляризациясе һәм изотоп-селектив фотохимик реакцияләр өлкәсендәге химик реакцияләрнең элементар механизмнарын өйрәнү өчен принципта яңа булган күп кенә физик-химик алымнар эшли. С. төшләрне стимуллы поляризацияләү алымын — эремәләрдәге арадаш радикаль парлар һәм бирадикалларның ЭПР спектрларын детекторлауны (сизгерлеге буенча магнит резонансының традицион алымнарыннан шактый югары); кыска вакытлы радикалларның икеле электрон-төш резонансы алымының яңа вариантын; молекулаларны химик реакцияләрдә радиоешлыклы зондлау алымын тәкъдим итә һәм үстерә. Катализаторларның магнит-резонанс интраскопиясенең яңа алымнарын; яңа типтагы магнитик актив материалларны химик конструкцияләүнең уникаль ысулларын эшли. Ростов ун-тының атказ. профессоры (1997), Мәскәү ун-тының шәрәфле д-ры (1999), Иркутск ун-тының шәрәфле профессоры (2000). Ленин бүләге (1986), РФ Дәүләт бүләге (1994) лауреаты. 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», Почёт орденнары, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Молекулярные ферромагнетики // Успехи химии. 1999. Т. 68, вып. 5 (автордаш); Динамическая и стимулированная поляризация ядер в фотохимических и радикальных реакциях // Успехи химии. 2000. Т. 69, вып. 11 (автордаш); Многоядерная магнитно-резонансная томография — многофункциональный инструментарий для исследования свойств материалов, процессов транспорта и каталитических реакций // Успехи химии. 2007. Т. 76, вып. 8 (автордаш); Spin Polarization and Magnetic Effects in Radical Reactions. Amst., 1984 (автордаш).

*Әд.:* Ренад Зиннурович Сагдеев (к 60-летию со дня рождения) // Изв. РАН. Сер. хим. 2001. № 12. *Р.Г.Усманов.*

**СӘГЪДИ́ЕВ** Роальд Зиннур улы (26.12.1932, Мәскәү), физик, физика-матем. фән. д-ры (1963), СССР ФА академигы (1968 елдан; 1964 тән мөхбир әгъзасы; 1991 дән — РФА академигы), ТР ФА академигы (1992), Соц. Хезмәт Герое (1986), ТР-ның атказ. фән эшлеклесе (2003), Казан ун-тының мактаулы д-ры (2007). Сьюзен Эйзенхауэрга — АКШның элекке президенты Дуайт Эйзенхауэрның оныгына өйләнә. 1955 тә Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, Атом энергиясе ин-тында эшли (Мәскәү, 1956–61). 1961–70 тә СССР ФА Себер бүлегенең Атом-төш физикасы ин-тында лаб. мөдире (Новосибирск ш.). 1970 тән Мәскәүдә: СССР ФАнең Югары температуралар физикасы ин-тында, 1973 тән директор, 1988 дән РФА Космик тикшеренүләр ин-тының баш фәнни хезмәткәре. 1989 дан ш.у. Мэриленд ун-ты (Вашингтон, АКШ) профессоры, «Восток-Запад» фәнни тикшеренүләр үзәген җитәкли. Халыкара космик фәзаны тикшерү ком-тының вице-президенты (КОСПАР, 1975 тән). Хәзерге заман плазма физикасын тудыручыларның берсе. Хезмәтләре плазма физикасына (бәрмә дулкыннар, күчерү процесслары, тотрыксызлык), гидродинамикага, идарә ителүле термотөш синтезы проблемасына, космик физикага карый. Тороидаль плазмада күчерү процессларының неоклассик теориясенә нигез сала. С. плазмада әтәргечсез дип йөртелүче бәрмә дулкыннар барлыгын ача (1964), плазмада көчле ярылулар таралу турындагы яңа төшенчәләрне үстерә. Югары темп-ралы плазма тудыру һәм аны куәтле магнит кыры б-н тотып тору максатындагы «Токамак» йомык магнит тозакларының үзлекләрен өйрәнә, «Токамак» җайланмаларында күчерү процессларының матем. теориясен үстерә. Җирне Космостан тикшерү, космик технологияләр, Җир магнитосферасына актив тәэсир итү өлкәсендә эшли. «Космос», «Прогноз», «Интеркосмос», «Метеор», «Астрон», «Марс», «Венера» серияле космик аппаратларда, «Союз», «Салют» орбиталь комплексларында куелган уникаль тикшеренү программалары б-н җитәкчелек итә. С. җитәкчелегендә «Союз-Аполлон», «Венера», «Лоцман», «Фобос» совет-америка һәм халыкара проектлары гамәлгә ашырыла. Халыкара «Вега» проектының фәнни җитәкчесе. Орбиталь комплекслар коруда Россия модульле принцибы кулланылган Халыкара космик станция (МКС) төзүне башлап йөрүчеләрнең һәм аны тормышка ашыручыларның берсе. АКШ белгечләре б-н берлектә бортына Россия «Ленд» нейтрон телескобы урнаштырылган Америка космик аппаратын су бозы ятмаларын тикшерү максатында галәмгә җибәрү буенча фәнни проектта катнаша. СССР, АКШ, ГФР һ.б. илләрдә нәшер ителгән «Физиклар өчен плазма физикасы» («Физика плазмы для физиков», М., 1979) монографиясенең автордашы. Галимнәрнең тынычлык өчен халыкара хәрәкәте лидерларының берсе; атом-төш куркынычына каршы СССР ФА каршында төзелгән Тынычлык сагындагы галимнәр ком-тын җитәкли. Женева (1985), Вашингтон (1987), Мәскәүдә (1988) уздырылган югары дәрәҗәдәге очрашуларда М.С.Горбачёв һәм Э.А.Шеварднадзеның киңәшчесе, гражданлык һәм хәрби-космик кораллану системаларына бәйле мәсьәләләр буенча М.С.Горбачёвның киңәшчесе була. Германия ФАнең Макс-Планк җәмгыяте, (1976), Халыкара астронавтика академиясе (1980), АКШ Милли ФА (1987), Корольлек астрономия җәмгыяте (1988), Швеция Корольлек академиясе (1988), Венгрия ФА (1988), Чехословакия ФА (1988), Ватикан ФА (1990), Америка сәнгать һәм фән академиясе (1991) әгъзасы. Тулуза (Франция), Грац (Австрия), Лос-Анджелес, Нью-Йорк, Мичиган (АКШ) ун-тлары һәм дөньяның башка фәнни үзәкләренең шәрәфле докторы. СССР ЮС депутаты (1987–89), СССРның халык депутаты (1989–91). Ленин бүләге (1984), Халыкара «Ел кешесе-87», Джордж Кеннан (АКШ, 1989), Вашингтон ФА (1998) һ.б. бүләкләр лауреаты. Ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, Йолдыз ордены (Венгрия), медальләр б-н бүләкләнә.


Роальд З. Сәгъдиев.

Х е з м.: Ударные волны в разреженной плазме // Вопросы теории плазмы. М., 1964. Вып. 4; Нелинейная теория плазмы // Вопросы теории плазмы. М., 1972. Вып. 7 (автордаш); Введение в нелинейную физику. М., 1989 (автордаш); Nonlinear Physics: From the Pendulum to Turbulence and Chaos // Contemporary Concepts in Physics. 1988. V. 4.


*Әд.:* Академик Роальд Сагдеев. К., 2007.

*Р.Г.Усманов.*

**СӘГЪДИ́ЕВА** Ләлә Гариф кызы (23.9.1935, Әлки р-ны Яңа Чаллы а.), агроном-селекция белгече, ТССРның атказ. агрономы (1991). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1958), Ташкент ботаника бакчасында эшли. 1962 елдан Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының селекция бүлегендә. Хезмәтләре тары селекциясе мәсьәләләренә карый. С. — «*Камское*», «*Казанское кормовое*», «*Татарское красное*», «*Удалое*», «*Нур*», «*Лучистое*», «Бәхетле» тары сортлары авторларының берсе. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм 1 патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының 1 көмеш, 1 бронза медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Крупяное поле Татарии. К., 1979 (автордаш); О некоторых результатах селекции проса на кормовые цели // Актуальные проблемы селекции и семеноводства зерновых культур юго-восточного региона Российской Федерации. Саратов, 1999 (автордаш).

**СӘГЪДУ́ЛЛИН** Шәрифулла Сәгъдулла улы (29.7.1930, Арча р-ны Үгез-Елга а. — 28.6.2001, Арча р-ны Шушмабаш а.), тракторчы-машинист, Соц. Хезмәт Герое (1976). Хезмәт эшчәнлеген 1946 елда Кызыл Юл р-ның «Шушма» к-зында башлый. 1957–59 да Казакъстан ССРның Көкчәтау өлкәсендә чирәм җирләрне үзләштерүдә катнаша, 1959–91 дә Арча р-ның «Северный» с-зында эшли. Техниканы камил белә, җирне сукалау һәм чәчү вакытында 2–3 смена нормасын үти. Герой исеме игенчелек продуктларын җитештерүдә һәм дәүләткә сатуда 9 нчы бишьеллык (1971–75) планны үтәүдә ирешкән уңышлары өчен бирелә. 1978–83 тә ТАССР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Арчада Соц. Хезмәт Геройлары аллеясында С. бюсты куелган.


Ш.С. Сәгъдуллин.

Х е з м.: Туган җирем — язмышым. К., 1986.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой славы — наши земляки. К., 2003.

**СӘГЫ́ЕВ** Садыйк Сәгый улы (28.12.1883, Казан — 1953), революцион хәрәкәттә катнашучы, партия эшлеклесе. Казанда туку ф-касында эшли (бүленеп: 1901–03 елларда Екатеринбург шәһәрендә туку фабрикасында). Татар эшчеләренең марксистик түгәрәгә әгъзасы (җитәкчесе — Х.М.Ямашев). Казанда 1905–07 еллардагы рев-ция вакыйгаларында катнаша. 1905 нең декабрендә кулга алына, 1906 ның апрелендә Екатеринбургка, аннан соң Пермь губернасының Чердынь шәһәренә җибәрелә. Сөргеннән качкач, Бакуда фабрикада, нефть промыселларында эшли; РСДРПның Балахан район ком-ты әгъзасы. 1910 да кабат кулга алына, 1912 дә, барлык хокуклардан мәхрүм ителеп, Иркутск губернасының Верхоленск өязенә гомерлек сөргенгә җибәрелә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Казанга кире кайта. Гражданнар сугышы вакытында Себердә яшерен эштә, Иркутск эшчеләренең кораллы күтәрелешендә катнаша (декабрь, 1919), рота командиры, Кызыл Армиядә бригада инструкторы һәм комиссар. 1921–24 тә РКП(б) Иркутск губерна ком-тының татар-башкорт бүлеге мөдире. 1924–26 да ВКП(б) ҮК каршындагы Татар-Башкорт бюросының җаваплы секретаре. 1927 дә ВКП(б) Татарстан өлкә ком-тының 2 нче секретаре. 1927 ел ахырыннан Коммунистлар академиясе каршындагы курсларда укый (Мәскәү). 1930 елларда Үзбәкстанда: Эшче-крәстияннәр инспекциясенең (ЭКИ) халык комис-ты коллегиясе әгъзасы. РКП(б) Үзәк контроль комиссиясе рәисе урынбасары, ЭКИнең халык комиссары урынбасары; Фирганә округының һәм Фирганә шәһәренең контроль комиссиясе һәм эшче-крәстияннәр инспекциясе рәисе; Үзәк контроль комиссиясе — эшче-крәстияннәр инспекциясенең җаваплы инструкторы, Үзбәкстан ССРның ҮБК каршындагы Кызыл партизаннар һәм кызылармиячеләр эшләре буенча үзәк комиссиянең әгъзасы һәм җаваплы секретаре, Урта Азия буенча әзерләүләр Дәүләт инспекциясе башлыгы. Соңыннан Казанда, Мәскәү янында яши.

*Әд.:* А н и с и м о в Н. Сагеев Садык Сагеевич // Борцы за счастье народное. К., 1967; Х а с а н о в Х.Х. Садык Сагеев. К., 1987.

**СӘГЫ́ЙД БИСТӘСЕ́**, к. *Каргалы бистәсе*.

**СӘГЫ́ЙД әл-БӘРӘСКӘВИ́** (?, Казан губ., Казан өязе Түбән Бәрәскә а. — 1855, Казан), дин эшлеклесе, илаһият галиме. Туган авылы мәдрәсәсендә башлангыч белем алганнан соң, Бохарада укый. Вятка губернасы Малмыж өязенең Түнтәр мәдрәсәсендә укыта. 1836 елдан Мәрҗани мәчетендә имам-хатиб һәм мөдәррис, бер үк вакытта Казанның Апанаев мәчете каршындагы мәдрәсәдә укыта. 1848 дә хаҗга бара. 1854 тә Оренбург Мөселманнары Диния нәзарәте рәисе урынбасары булып эшли, Россия эчке эшләр министры урынбасары күрсәтмәсе буенча эшеннән азат ителә. Хезмәтләре илаһият гыйлеменә карый.

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

**СӘГЫ́ЙД әл-БАРЫШИ́** (18 йөзнең 2 нче яртысы, Казан губ., Тәтеш өязе Барыш а. — 1813, Казан өязе Кышкар а.), дин эшлеклесе, илаһият галиме. Барыш авылында мәдрәсә тота. 1796 елдан — Кышкар авылы мәчетендә имам. Хезмәтләре илаһият гыйлеменә, астрономия өлкәсенә карый.

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

**СӘГЫ́ЙД әш-ШЫРДАНИ́** (?, Казан губ., Зөя өязе Олы Шырдан а. — 1831, Казан), дин эшлеклесе, илаһият галиме. 1776–81 елларда Казан губернасындагы Арча өязенең Югары Сәрдә авылында мулла, соңрак Яңа Кишет авылында имам һәм мөдәррис була. 1810 нан Казандагы 5 нче мәчеттә имам һәм мөдәррис. 1829 да юл уңаеннан Истанбулга керү нияте б-н хаҗ кылырга китә, ләкин, рус-төрек сугышы башлану сәбәпле, Кырымнан әйләнеп кайтырга мәҗбүр була. Хезмәтләре илаһият гыйлеменә карый.

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

**СӘГЫЙДӘ́** (псевд., чын фамилиясе Якупова-Бакирова) Зәйнәп Хәлиулла кызы (22.4.1897, Оренбург губ. Каргалы бистәсе — 1994, Ташкент), язучы. Оренбург мәдрәсәсендә белем ала. 1914 елдан башлап кызлар мәктәбендә укыта. Беренче әсәрләре 1915 тә «Шура» ж-лында, «Вакыт» г-тасында басыла башлый. С. — социаль юнәлештәге шигырьләр авторы. Ул шигырьләрендә җәмгыятьтәге тигезсезлеккә, гаделсезлеккә карата протест белдерә. «Пугачёв турында Каргалы легендасы» (1916) исемле тарихи поэманың үзәгендә изелгән катлау мәнфәгатьләрен яклаучы каһарман герой образы тора. «Җүләр егет» (1915) исемле хикәясендә кеше гомеренең кыйммәте турында яза. Окт. рев-ясеннән соң хатын-кызлар арасында мәдәни-агарту эше б-н шөгыльләнә, мәктәптә укыта. 1921 дә Үзбәкстанга китә, Үзбәкстан ССР ХКС нәшриятында корректор булып эшли.

*Әд.:* Өмет йолдызлары: XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы татар хатын-кыз язучылары әсәрләре. К., 1988.

*Р.Ф.Мәрданов.*

**СӘГЫЙДИ́** Әбрар Мөхәммәтзакир улы (1.4.1895, Казан губ., Зөя өязе Кошман а. — 14.4.1939, шунда ук), шагыйрь. 1908–16 елларда Казанда «Мәрҗания» мәдрәсәсендә, Укытучылар семинариясендә укый. Авыл мәктәпләрендә укыта. 1918–20 дә «Эшче», «Эш», «Татарстан хәбәрләре» г-таларында, 1925–27 елларда Зөя кантоны башкарма ком-тында, 1927 дән соң халык мәгарифе өлкәсендә эшли. 1913 тән «Кояш», «Тормыш», «Кызыл Армия» г-таларында, «Шура», «Ак юл», «Сөембикә» ж-лларында басыла башлый. 1917 дә «Ирек азаны», «Сугыштан абыем хатлары» исемле шигъри җыентыкларын бастыра. Бу елларда С. иҗатының төп темалары — ирекле хезмәт, эшче һәм крәстияннәр берлеге, интернационализм идеяләре, рев-циягә кадәрге һәм хәзерге тормышны капма-каршы куюу. «Яшьләр иле» (1921) җыентыгына кергән шигырьләрендә агитация рухы, лозунг, риторика өстенлек итә. Татар теленә Р.Тагор, У.Уитмен, Д.Бедный әсәрләрен тәрҗемә итә. Драматургия жанрында да үзен сынап карый («Сахра кызы», 1929 да Татар акад. театрында куела, «Ишан улы», «Кызыл тау»).

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Библиогр. сүзлек. К., 2005.

**СӘГЫ́ЙДОВ** Кәрим (Габделкәрим) Мөхәммәтша улы (1888, Казан губ., Тәтеш өязе Кыр Тәүгелдесе а. — 25.8.1939, Амур өлкәсенең Свободный ш.), тюрколог, журналист, җәмәгать эшлеклесе, Г.Ш.*Шәрәф* туганы. Буа шәһәрендә мәдрәсә тәмамлаганнан соң (1905), үзлегеннән белем ала: төрки, гарәп, фарсы телләрен өйрәнә. Бер үк вакытта С.-Петербургтагы Казан һәм Мәскәү газеталарында хәбәрче булып эшли. 1917 елның апрелендә «Татар учагы» исемле студентлар түгәрәге вәкиле буларак Бөтенроссия мөселман гаскәриләре киңәшмәсендә (1917 ел, 27–30 апрель), Беренче Бөтенроссия мөселманнары корылтае эшендә (1917 ел, 1–11 май) катнаша, анда ул Милли Идарә әгъзасы итеп сайлана. 1918 нең февраль–апрель айларында «Шималь ягы» (Петроград) г-тасы нашире һәм мөхәррире; мөселманнарга «Госман Коръәнен» тапшыруда катнаша. 1920–30 елларда Казанда журналистика һәм фәнни тәрҗемә б-н шөгыльләнә, татар теленә табигыять һәм техник фәннәрдән дәреслекләр тәрҗемә итә. 1934 тән Ленинградта: СССР ФА-нең Көнчыгышны өйрәнү ин-тында фәнни хезмәткәр; В.А.Зәбиров б-н бергә СССР халыклары тарихы буенча кульязма чыганаклар өйрәнә. Бер үк вакытта Тарих-археография ин-тында эшли. 1936 да кулга алына, хезмәт б-н төзәтү лагерена 5 елга хөкем ителә; төрмәдә үлә. Хезмәтләре татар халкының иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади, этномәдәни тарихына карый.

Хезм.: Авыл баласы. К., 1910; Татарстан кантоннарында сәүдә-сәнәгать эшләре // Безнең юл. 1923. № 10/11; Зоология (Хайванат): 2 бүлектә. К., 1925 (автордаш); Әзәрбайҗан һәм Кырым театрлары // Татар театры (1906–1926). К., 1926; Аталар тирәсендә // Мәгариф. 1928. № 1.

*Әд.:* Сагыйдова Э. Галим, педагог, журналист... // Казан утлары. 1990. № 1; Люди и судьбы: Биобиблиогр. словарь востоковедов — жертв политического террора в советский период (1917–1991). СПб., 2003.

*Җ.С.Миңнуллин.*

**СӘГЫ́ЙДОВА** Энҗе Кәрим кызы (10.5.1921, Казан — 8.12.1997, С.Петербург), библиограф, китап гыйлеме белгече, филол. фән. канд. (1956). «*Шималь ягы*» г-тасы нашире К.М.*Сәгыйдов* кызы, Г.*Шәрәфнең* туганының кызы. 1948 елда Ленинград ун-тының шәрекъ ф-тын тәмамлаганнан соң, Дәүләт җәмәгать китапханәсенең милли әдәбият бүлегендә (С.-Петербург, хәзерге Россия милли китапханәсе) эшли, 1974 тән бүлек мөдире. СССРның барлык союз респ-каларының дәүләт телләрен, ш.у. фин телен белә. «СССР халыклары телләрендә вакытлы һәм дәвамлы басмалар каталогы»н (СПб., 1993) редакцияли, китап, журнал, газета елъязмаларын, тематик библиографияләр һәм күптомлы Татар энциклопедиясенең генераль лөгатьлеген төзүгә зур өлеш кертә. Дуслык ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Первое и последнее прижизненные издания Тукая // Tatarica. Hels., 1987; Взаимопроникновение культур финно-угорских народов // Библиотека. 1998. № 6.

*Э.В.Тисенко, А.С.Асватуров.*

**СӘГЫЙДУ́ЛЛИН** Габдулла Гайфулла улы (30.6.1938, БАССРның Аургазы р-ны Түбәнге Ләкәнде а. — 1999, Уфа ш.), шартлау физикасы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1978), проф. (1980). 1965 елда Ленинград технол. ин-тын тәмамлый. 1965–68 дә — «Союзмашпроект» тармак проект ин-тында (Мәскәү); 1968–98 дә Мәскәү химия машиналары ин-тында эшли, 1994 тән Шартлату технологияләре үзәген оештыручы һәм аның җитәкчесе. 1987 дә Бөтенсоюз үткәргеч торбалар төзү фәнни-тикшеренү ин-тында шартлату технологияләре һәм аппаратурасы лаб-ясен оештыра һәм җитәкли. 1998 дән Энергия ресурсларын транспортлау проблемалары ин-тында шартлату технологияләре бүлеге мөдире (Уфа ш.). Хезмәтләре шартлау физикасына һәм детонация процессларына карый. С. халык хуҗалыгында ышанычлы шартлату чаралары сыйфатында кулланыла торган яңа конструкцияле детонация шнурларының фәнни нигезләрен булдыра һәм аларны исәпләүнең инженер алымнарын эшли. Детонация импульсын ерак араларга көпшәсыман тышчаны җимермичә тапшыра торган дулкын йөрткечкә нигезләнгән нәэлектрик шартлату системалары авторы. С. металл конструкцияләр, бетон, тимер-бетон, таш, агач кисү өчен яңа типтагы зарядлар булдыра; эшләп торучы үткәргеч торбаларны төзәтүдә һәм яңадан торгызуда кулланыла торган зарядларны камилләштерә. 150 фәнни басмасы, уйлап табуга 70 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

*Әд.:* Специалисты по взрывчатым материалам, пиротехнике и боеприпасам: Биогр. энцикл. М., 2006.

**СӘГЫЙДУ́ЛЛИН** Миңлегәрәй Сәгыйдулла улы (18.4.1900, Уфа губ., Минзәлә өязе Югары Суыксу а. — 10.5.1938, Казан), сәясәт эшлеклесе, публицист. 2 ел эчендә чиркәү-мәхәллә уч-щесен (имтихан тапшырып), Я.М.Свердлов исем. ун-т каршындагы кыска вакытлы теоретик курсларны тәмамлый (Мәскәү, 1921). Игенчелек б-н шөгыльләнә, этисе б-н читкә китеп эшли. 1918 елда туган авылында Эшче-крәстиян яшьләр союзының (РКСМ) авыл оешмасын, ярлылар ком-тын оештыра. 1919–20 дә РКСМның Минзәлә

өяз ком-тында, авыл һәм волость советларында, «волнрав»та, волость загсында эшли. Мөселман руханиларыннан туу, никахлашу, үлү актларын рәсми рәвештә теркәп бара торган төп кенәгәләрне алуда катнаша: бер үк вакытта «Роста» һәм «Игенче» г-таларының мөхәрририятләре әгъзасы. 1921 дән совет партия мәктәбенең өяз уку-укыту бүлеге мөдире, сәяси мәгариф йортының кантон бүлеге рәисе, 1922 дән РКП(б)ның Минзәлә канткомы 1 нче секретаре, ТАССР ҮБК әгъзасы. 1923–25 тә РКП(б)ның Казан берләштерелгән бистәләр район ком-ты секретаре. 1925–26 да ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тының оештыру, агитация-пропаганда бүлекләре мөдире. 1926 ның февралендә Урта Азиягә партия эшенә җибәрелә. 1927 ел башында Казанга кайтканнан соң, фәнни-тикшеренү һәм журналистика эше б-н шөгыльләнә башлый. Окт. рев-циясенең 10 еллыгына «Бөек Октябрь юлларында татар хезмәт ияләре» («Татарские трудящиеся на путях Великого Октября», 1927) исемле монографик хезмәтен яза. Анда ул Татар җәмәгатьчелегенең төрле иҗтимагый-сәяси оешмаларының (ш.и. Мөселман соц. ком-тының) эшчәнлеген анализлый, «Болак арты республикасы» дип аталган дәвернең сәяси идеяле агымнарына бәя бирә; партиягә яраклашып Татар дәүләтен Идел-Урал Штаты рәвешендә оештыруга каршы чыга, әмма бу С.га Мөселман соц. ком-ты әгъзаларының фотосурәтен бастыруга комачауламый, алар арасында партиядән куылган М.Х.Солтангалиев тә була. 1928 нең 10 февралендә ВКП(б)-ның Татарстан өлкә ком-ты, китапта хаталар җибәргәне өчен, С.ны шелтәле һәм, сәяси көрәштә гаепләп, өлкә ком-ты җитәкчелеге алдында аны ВКП(б)ның ҮБК карамагына эшкә җибәрергә кирәклеге турындагы мәсьәләне куя. Окт. рев-циясенең 11 еллыгына «Красная Татария» г-тасы редакциясе үтенече б-н С. «Сыйнфый көрәшнең җанлануы һәм милли мәсьәлә» («Оживление классовой борьбы и национальный вопрос») исемле мәкаләсен яза. Анда ул илдә кискенләшкән иҗтимагый-сәяси хәл милли мәсьәләне яңадан көн тәртибенә кертүне таләп итә, дип билгели. Мәкалә басылмый, аның урынына «Кызыл Татарстан» г-тасында С.ның «Тарих заманга карата аяусыз» («История безжалостна ко времени», 1928) исемле башка мәкаләсе басыла. Мәкаләдә Окт. рев-циясеннән соңгы 11 ел эчендә пролетариат сыйфат ягыннан ныгый, татар милләтчеләре партия бюрократиясенә каршы көрәш башлыйлар дип әйтелә. 1929 да шул ук газетада «Куштаннар токымы» («Племя подхалимов») исемле сәяси памфлеты басыла. Анда С. татар җитәкчеләре арасындагы сәяси ялагайлык формаларын тәнкыйтьли, хезмәткәрләргә тупас мөнәсәбәттә булып, җитәкчелек алдында «тәлинкә тотуны» фаш итә. Памфлет җәмәгатьчелек арасында кызыксыну уята. ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты бюросы мәкалә турында сәяси әңгәмә оештыра, һәм ул «... большевиклар партиясе нигезләренә каршы яшерен атака», халык арасында партиянең абруен какшата, «партия сафларын таркалган элементлардан чистарту эшенә зыян китерергә мөмкин» дигән карар чыгара. 1929 ның ахырында С. журналистика эшенә Төньяк крайга күчерелә. 1930–32 дә Кызыл профессура ин-тының филос. бүлегендә укый (Мәскәү). Төп хезмәтләре татар милли-демократик һәм вәисиләр хәрәкәтенә багышлана. 1932 нең 21 декабрендә «Татарстанның сул карашлы контрреволюцион милли оешмасы» җитәкчесе буларак кулга алына, «Крәстияннәр иттифагы» партиясен оештыруда гаепләнә, үлем җәзасына хөкем ителә, үлем җәзасы 10 елга ирегеннән мәхрүм итү б-н алыштырыла (к. «*Милләтчеләрнең контрреволюцион-фетнәчел оешмасы» эше*). Шул дәвердәге документларның берсендә М.С.Сәгыйдуллин, Г.Н.Әминов, И.Ш.Галиев, Г.С.Баембәтов турында: «Хәзер без, алар империалист агентларга әверелделәр дип, дәлилле алабыз. Бернинди Польша штабы да, бернинди Милюков та, бернинди Керенский да башка программа теләмәячәкләр. Солтангалиевчелектән дә начаррак нәрсә бармы дисәк, баембәтчелек, әминовчылык, сәгыйдуллинчылык солтангалиевчелектән начаррак», — диелә. С. срогын «Дмитровлаг»та (Мәскәү өлкәсе) тутыра, күптиражлы газета редакциясендә эшли, аннан соң Соловки утрауларына этап б-н озатыла. 1937 дә Казанга җибәрелә, монда аны «*Троцкийчы милләтчеләрнең контрреволюцион-террорчылык оешмасы» эшендә* катнашуда гаеплиләр. 1938 нең 10 маенда СССР Югары мәхкәмәсе Хәрби коллегиясенең күчмә сессиясе С.ны атарга хөкем итә. Үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Татарские трудящиеся на путях Великого Октября. К., 1927; К истории ваисовского движения. К., 1930.

*Әд.:* Л и т в и н А.Л. Без права на мысль (Историки в эпоху Большого террора: Очерки судеб). К., 1994. *Р.В.Шәйдуллин.*

**СӘГЫ́ЙРОВ** Гакыйль Шәрифулла улы (15.2.1938, Куйбышев (хәзер Самара) өлкәсенең Кошки р-ны Иске Җүрәй а. — 29.7.2009, Димитровград ш., туган авылында җирләнә), шагыйрь, рәссам-график. Н.К.Крупская исем. Бөтенсоюз сәнгать ин-тында укый (1963–65). 14 яшьтән урын өстендә: карандашны тешләренә кысып язарга, рәсем ясарга өйрәнә. Беренче шигырьләре 1960 елда Нурлат шәһәрендә чыга торган «Дуслык» г-тасында басыла. «Тормыш җиле» (1970), «Айбагарлар» (1983), «Кабатланмас моң»=«Неповторимая мелодия» (1994), «Ике кояш» (2000), «Йөрәк сере» (2006) исемле җыентыклар авторы. Китаплары, нигездә, үзе ясаган рәсемнәр б-н бизәлгән. Шигырьләрендә яшәргә омтылыш, һәрнәрсәдә үзе катнашырга теләү мотивлары өстенлек итә. 2002 дә Самара шәһәрендә С.ның рәсемнәр күргәзмәсе оештырыла. Ул — сынлы сәнгать өлкәсендә Халыкара «Филантроп» бүләге лауреаты. Публицистик мәкаләләре матбугатта басыла.

*Әд.:* Г а л и у л л и н Т. Рух бөеклеге // Казан утлары. 2008. № 2.

**СӘГЫЙТДИ́НОВ** Исмәгыйль Вәлиулла улы (20.1.1930, Чистай р-ны Гаделша а. — 14.6.2006, Зәй р-ны Түбән Биш а.), галим агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. агрономы (1974), РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1984). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1957). 1949–57 елларда Чистай р-ны дәүләт орлык сыйфаты инспекциясендә агроном-инспектор булып эшли. 1958–59 да Зәй районы а.х. инспекциясендә баш агроном. 1959–93 тә Зәй р-ның Тукай исем. к-з рәисе. С. җитәкчелегендә колхозда барлык терлекчелек биналары һ.б. җитештерү, социаль-мәдәният һәм көнкүреш объектлары төзелә һәм яңартыла. Бөртекле ашлык җитештерү – 2 тапкыр, сөт 5,7 тапкыр арта; шикәр чөгендереннән тулай җыемы 8,6 мең *т* га җитә; бөртекле культураларның уңышы – 1 *га* дан 9,1 *ц* дан 24,7 *ц* га, шикәр чөгендере — 7,1 *ц* дан 215,5 *ц* га, бәрәңге 36,8 *ц* дан 103,3 *ц* га арта; һәр сыердан еллык савым уртача 2608 *кг* нан 3002 *кг* га арта. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**СӘГЫ́ЙТОВ** Абдулла Кыям улы (25.8.1918, Самара губ., Ставрополь өязенең Татар Калмаюры а. — 7.1.2013, шунда ук), зоолог, биол. фән. д-ры (1967), проф. (1968), Үзбәкстан ССРның атказ. фән эшлеклесе (1977). Сәмәрканд ун-тын тәмамлый (1941), шунда ук эшли, умырткалылар зоологиясе каф. мөдире (1962–88). 2000 елдан Бөек Новгород шәһәрендә яши. Хезмәтләре орнитофауна, экология, табигатьне саклауга карый. С. кошларда өстәмә нервларның (Nerus accesorius) баш миеннән мөстәкыйль чыгуларын исбатлый. Урта Азиядә беренчеләрдән булып кошларның оялап яшәвен өйрәнә. Халыкара орнитология җәмгыяте әгъзасы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Анатомическое строение первых шести пар головных нервов птиц. Самарканд, 1950; Экология гнездования массовых видов птиц Юго-Западного Узбекистана. Таш., 1980 (автордаш); Птицы Узбекистана. В 3 т. Таш., 1987–95 (автордаш).

**СӘГЫ́ЙТОВ** Марат Әбрар улы (3.10.1929, Кайбыч р-ны Кече Кошман а., хәзер Кошман а. – 6.3.2017, Казан), тел галиме, филол. фән. канд. (1964), РФнең мактаулы югары белем мәктәбе хезмәткәре (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1952), Татар гуманитар-пед. ун-тында эшли (2003 тән татар тел белеме каф. профессоры, 2007 дән гомуми һәм чагыштырма тел белеме каф. профессоры). Хезмәтләре татар теле фонетикасы, морфологиясе, стилистикасына, татар тел белеме тарихына карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Фонология: идеи и проблемы. К., 1972; Искусство слова в произведениях Г.Ибрагимова. К., 1974; Татарское языкознание за 50 лет. К., 1976.

**СӘГЫ́ЙТОВ** Мөхәммәдйосыф Габдесаттар улы (1830 — 14.1.1908, Казан), дин эшлеклесе. 1868 елдан Галиев мәчетендә (Казан) икенче мулла (1875 тән имам-хатип). *Кадимчелек* тарафдары буларак та билгеле шәхес. 1882 дә, мәхәлләнең икенче мулласы итеп билгеләнгән Г.Баруди яңача укыту ысулы кертә башлагач, С. аның идеологик оппонентына әйләнә, үз тирәсенә мәхәлләнең иң консерватив фикерле әгъзаларын туплый. Ф.Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» повестендагы төп геройның прототибы.

*Әд.:* С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Исторические мечети Казани. К., 2005.

**СӘГЫ́ЙТОВ Р. БАСМАХАНӘСЕ́**, Казандагы беренче хосусый татар басмаханәсе. 1843 елда Рәхимҗан Сәгыйтов тарафыннан Яңа Татар бистәсендә ачыла, 1862 гә кадәр эшли. 80 нән артык исемдәге китап басыла, алар арасында Коръән, «Кыйссаи Йосыф», «Таһир һәм Зөһрә», «Бакырган китабы», башка рухи мөселман әдәбияты, мәдрәсә өчен дәреслекләр һәм әлифбалар бар. 1845 тә басмаханә эшчәнлеге туктатыла, Казан губернаторы күрсәтмәсе нигезендә Р.Сәгыйтовтан 4 мең данә Коръән алына. Эчке эшләр министры боерыгы б-н бер елдан алар хуҗасына кайтарыла һәм басмаханә кабат эшли башлый, әмма Коръән нөсхәләре бик астына куела һәм аларны сату тыела, басмаханә полиция күзәтүендә була. Хакимият күрсәтмәсе буенча Казан ун-ты басмаханәсе Р.Сәгыйтов өчен гарәп шрифтлары коюдан баш тарта, бу исә басма сыйфатында чагылмый калмый. 1862 дән соң Р.Сәгыйтов үз эшчәнлеген нашир буларак дәвам итә, заказларын ун-т һәм Н.П.Коковин басмаханәләренә бирә.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. У истоков татарской книги. К., 1992; Габдельганеева Г.Г. Полиграфия и печать в Казанской губернии. 1800–1917 гг. К., 2005.

*Г.Г.Габделганиева.*

**СӘГЫ́ЙТОВ** Рәхимҗан (1821–1863), нашир, полиграфист. 1843 елда Казанда беренчеләрдән булып шәхси басмаханә ача (к. *Сәгыйтов Р. басмаханәсе*). Татар полиграфиясе һәм наширлек эше үсешенә зур өлеш кертә; аның басмаханәсендә 80 төрле исемдә китап, ш.и. К.Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы (1846; 4 басма. 1849) басыла.

*Ж.С.Миңнуллин.*

**СӘГЫ́ЙТОВ** Тәүфикъ Камәретдин улы (1.5.1937, Буа р-ны Каенлык а.), журналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1977), тарих фән. канд. (1979), Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлый (1965). 1961 елдан «Татарстан яшьләре» г-тасында әдәби хезмәткәр. 1963–80 дә хәбәрче, ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение ком-тында сәнәгать тапшырулары бүлеге мөхәррире. 1980 нән Бөтенсоюз совет сәүдәсе ин-тының Казан ф-лында КПСС тарихы каф. укытучысы. 1984 тән «Татарстан» дәүләт телерадиотапшырулар компаниясендә рәис урынбасары, 1992–96 да Телевидение һәм радиотапшырулар ком-ты рәисе, 1996–2002 дән Телевидение һәм радиотапшырулар попечительләре советы рәисе, 2002 дән директор урынбасары. Дәүләт телевидение һәм радиотпашырулар ком-тының радиотапшырулар хезмәте башлыгы. Бер үк вакытта Казан химия-технол. ин-тында укыта (1979–89). Татарстан нефтьчеләренә, нефть химиясе сәнәгате үсешенә, КамАЗ төзелешенә (Х.Ямашев исем. бүләк, 1974) багышланган радиотапшыру циклы; тарих һәм иҗтимагый-сәяси проблемаларга караган очерк һәм мәкаләләр, Г.К.*Гыйматдинов* эшчәнлеге турында истәлекләр һ.б. авторы. ТР Журналистлар берлегенең «Бәллүр каләм — Хрустальное перо» бүләге лауреаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Замандашлар адымы. К., 1967; Буыннар язмышы. К., 1969; Язмыш хуҗасы. К., 1970.

*Әд.:* Игелекле тормыш // Мирас. 1994. № 1; Ике тормыш — бер язмыш // Чорлар кайтавазы. К., 2005; Говорит Казань. К., 2008.

**СӘГЫ́ЙТОВА** Римма Надыйр кызы (19.6.1961, Казан), химик-органик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000), химия фән. канд. (1988). 1983 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1986 дан Казан аграр ун-тының гомуми химия кафедрасында эшли. Хезмәтләре ацилизоцианатларның төзелешен һәм реакциягә сәләтен тикшерүгә карый. С. ацилизоцианатларның алифатик азиннар һәм кайбер бензальаминнар б-н үзара тәэсирен тикшерә. Дәүләт бүләге күп максатлы комплекслы хелат микроашламалар уйлап табуда һәм аларны гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 9 патенты бар.

Хезм.: Исследование электронной и пространственной структуры ацилизоцианатов квантово-химическими методами // Докл. АН СССР. 1983. Т. 273, № 4 (автордаш).

**СӘДАКА́** (гарәп. صدقة — чын күңелдән эшләнгән эш), һәр хәлле мөселманның Коръән кушуы буенча мохтаҗларга бирә торган хәере. Йолу корбаны; мохтаҗларга бирелә торган хәер; акча кеременең бер өлешен җирле мөселман җәмгыятенә ярлылар, инвалидлар, матди авырлык кичерүчеләр, мосафирлар файдасына күчерү рәвешендә башкарыла. Диндарлар фикеренчә, С. гөнаһлардан арыну акты; турыдан-туры бүләк итүченең үзе яки рухани затлар тарафыннан өләшенергә мөмкин. С. б-н бергә шәригать мөселманнарга мохтаҗлар файдасына *зәкят* түләргә дә куша.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**СӘДӘ́Ф УТЫ́** (Lithospermum), кыярчалар семьялыгыннан бер-, ике-, күпьеллык үләннәр, ярымкуак һәм куаклар ыругы. 60 ка якын төре билгеле, күбесе Төньяк ярымшарда очрый. ТР терр-ясендә 2 төре бар. Басу С.у. (L. arvense) — 15–45 *см* биеклектәге берьеллык, дарулы С.у. (L. officinale) — 30–80 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Коры тау битләрендә, Кама аръягы кырларында, куаклар арасында үсәләр. Сабагы тармаклы, туры. Яфраклары утырма, ланцетсыман, кытыршы. Чәчәкләре вак, аксыл-сары, тоташ үскән таҗлы. Җимеше — чикләвекчек. Май–августта чәчәк аталар. Тамырларында буяу матдәләре бар. Халык медицинасында дарулы С.у.ның җир өсте өлешләре бәвел кудыру, эч йомшарту, авыртуны басу чарасы буларак кулланыла.

**СӘЕ́Д** (гарәп. سيد — юлбашчы, башлык, әфәнде), 1) Мөхәммәд пәйгамбәр нәселенең шәрәфле титулы (аның оныгы Хөсәен нәселенә барып тоташкан С.ләр тармагы аеруча хөрмәтләнә); 2) татар ханлыкларында (Казан, Касыйм, Кырым, Әстерхан, Себер ханлыкларында), Нугай Урдасында мөселман руханилары башлыгы. Идел буенда беренче тапкыр Алтын Урда чорында күренә: мәгълүм булганча, ислам *Үзбәк хан* тарафыннан дәүләт дине итеп игълан ителгәндә, Сәед-Ата катнаша. Нәтиҗәдә, С.ләр татар ханнарының хакимлек итүче төркеменә керәләр, дәүләт эшләрендә, дипломатик сөйләшүләрдә, хәрби походларда, хан сайлаганда, аңа ант иткәндә катнашалар. Казан ханлыгы С.ләре: Тәвәккәл, Касыйм (1492 гә кадәр), Бураш (1491–1507, башка чыганаклар буенча, 1524 кә кадәр), Шаусәен (Шаһ-Хәсән) (1512 дән), *Боерган Сәед* (1524–46 да булуы ихтимал), *Мансур* (1546–52; Д.М.Исхаков фаразлавынча, 1546–51 дә Колмөхәммәд С. була), *Колшәриф* (1551–52). Казан ханлыгында С. турында соңгы хәбәр (Хөсәен) 1554 кә карый. Хәзерге татар телендә «С.» сүзе ялгызлык исемнәрдә компонент буларак очрый (Мирсәед, Сәетгали, Сәетәхмәт һ.б.).

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989; Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах: В 4 ч. СПб., 1863–87; Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Исхаков Д.М. Сеиды в позднезолотоордынских татарских государствах. К., 1997.

**СӘЕ́Д ӘХМӘ́Д** (якынча 1410–1456 елдан соң), *Олы Урдага* нигез салучы һәм ханы (1430 еллардан башлап). *Кәримбирде ханның* улы. *Олугъ Мөхәммәд* сараенда була, 1430 еллар уртасында, Олугъ Мөхәммәднең *Кече Мөхәммәд* б-н үзара сугышларыннан файдаланып, Кырымны яулап ала һәм үзенең олысына әверелдерә. 1440 еллар башында Алтын Урданың көнбатыш өлешен, Кара диңгез буе далаларын яулап ала. Подолье (1442, 1447), Бөек Литва кенәзлегенә (1444), Мәскәү кенәзлегенә (1449, 1451) яулар оештыра. Мәскәүнең бөек кенәзе Василий II не Урдага кабат ясак түләргә мәҗбүр итә. 1456 да Бөек Литва кенәзлегенә каршы яуда кенәз Семён Олельковичтан җиңелә; әсирлектә үлә.

*Әд.:* Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

*И.Л.Измайлов.*

**СӘЕ́Д БОРҺА́Н ХАН** (1624–1680 тирәсе, Мәскәү), Касыйм ханы (1627–79). *Арслан хан* б-н *Фатыйма Солтанның* улы. Атасы вафатыннан соң Касыйм тәхетенә утыртыла. Балигълык яшенә җиткәнче ханлык б-н анасы һәм бабасы Акмөхәммәд сәед идарә итә. С.Б.х. балигъ булгач, патша Алексей Михайлович аңа кызына өйләнергә тәкъдим итә. Моңа Фатыйма Солтан каршы чыга. С.Б.х. хакимияте вакытында ханлык б-н идарә итү тулысынча рус патшасы вәкилләре кулында була, ханлыкта руслар тарафыннан көчләп чукындыру, чукынмаганнарның милек хокукларын чикләү башлана. С.Б.х. 1679 да тәхеттән ваз кичә, чукынып, Василий исемен ала.

*Әд.:* Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1866. Ч. 3.

*И.Л.Измайлов.*

**СӘЕ́Д ХАН** (? — 1587 дән соң), Себер ханы (1586–87). *Ядегәр* ханның улы. Атасы *Күчүм хан* тарафыннан үтерелгәннән соң (1563), Бохарага качарга мәҗбүр була. Казак атаманы Ермак отрядларына каршы сугышта катнаша, 1585 елда *Карачыбәк* б-н бергә җиңеләләр. Ермак үлеменнән соң (1585), Күчүм *Кашлык* шәһәрен ала. Карачыбәк ярдәмендә С.х. тәхетне яулауга ирешә. 1587 дә Д.Чулков һәм М.Мещеряк житәкчелегендәге рус отрядлары б-н сугышта җиңелә, әсир төшә;

Мәскәүгә озатыла һәм анда патша хезмәтенә билгеләнә.

*Әд.:* Миллер Г.Ф. История Сибири. М.–Л., 1937. Т. 1; Скрынников Р.Г. Сибирская экспедиция Ермака. Новосиб., 1986.

*И.Л.Измайлов.*

**СӘЕ́Т** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 30 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ургыды елгасы буенда. 2010 елда 155 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1735 тән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы дәүләт крәстияннәре һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, 2 ярма яргыч, тимерчелек эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1135,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бишенде-Останково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 202, 1859 да — 576, 1897 дә — 887, 1920 дә — 727, 1926 да — 542, 1938 дә — 521, 1949 да — 284, 1958 дә — 229, 1970 тә — 234, 1979 да — 162, 1989 да — 100, 2002 дә — 144 кеше.

**СӘЕ́Т** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 104 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Казан ханлыгы чорыннан билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.тә чиркәү (1916 да төзелә), чиркәү-приход мәктәбе (1868 дә земство укырга-язарга өйрәтү мәктәбе буларак ачыла), почта станциясе, 6 җил тегермәне, сыраханә, 1 казна шәраб һәм 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2010 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ташёвка волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 288 ир-ат; 1859 да — 828, 1897 дә — 1054, 1908 дә — 1211, 1920 дә — 1289, 1926 да — 1281, 1938 дә — 734, 1949 да — 532, 1958 дә — 532, 1970 тә — 352, 1979 да — 231, 1989 да — 137, 2002 дә — 132 кеше. С. тирәсендә 16 йөзнең эпиграфик истәлекләре — кабер ташлары сакланган.

**СӘЕ́Т БИСТӘСЕ́ МӘДРӘСӘСЕ́**, Оренбург шәһәре янында *Каргалы бистәсе* мәчетләре каршында булдырыла. Беренче мәдрәсә — 1746 елда, 2 нче мәчет каршында — 1760 та, 3 нче мәчет каршында — 1773 тә, 4 нчесе каршында — 1789 да, 5 нчесе каршында — 1805 тә ачыла. 1869 да — 9 (5,5 мең шәкерт укый), 20 йөз башына — 10 (700 шәкерт) мәдрәсә була. С.б.м. мөселман мәгарифе үсешендә, бигрәк тә 18 йөзнең 2 нче яртысында — 19 йөз башында әһәмиятле роль уйный, бу чорда мәдрәсәләр аша Россия мөселманнары арасында Урта Азия (Бохара) укыту системасы киң тарала. Р.Фәхретдин 18 йөзнең 2 нче яртысын татарлар һәм башкортларның мөселман мәгарифе тарихында «Каргалы чоры» дип атый. Мәдрәсә эшчәнлегенең беренче унъеллыкларында мөдәррисләр булып, башлыча, Урта Азиядән чыгучылар эшли, соңрак Бохарада белем алган татарлар һәм башкортлар (иң күренеклеләре *Габдессәлам бине Ураи, Ишнияз бине Шириияз, Габдрахман бине Мөхәммәд әл-Кирмәни*) укыта. Укыту дәрәҗәсе еллар узу б-н үзгәрә, һәр мәдрәсәдә укыту дәрәҗәсенең күтәрелүе яки төшүе мөдәррисләргә һәм хәйриячеләрнең акчалата ярдәменә бәйле була. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Г.Хөсәенов булышлыгы б-н (к. *Хөсәеновлар*) 4 мәдрәсәдә яңа ысул б-н укыту башлана, калганнары ябылганга кадәр кадими булып калалар. С.б.м.ндә булачак атаклы мөдәррисләр, дин белгечләре һәм язучылар — Г.*Утыз Имәни*, Ә.*Каргалый*, Г.*Рахманколый*, Һ.*Салихов*, *Нигъмәтулла әл-Эстәрлебаш*, Габәйдулла бине Ибраһим бине Ишкуат (*«Габәйдия»* мәдрәсәсен нигезләүче), мөфтиләр — М.*Хөсәенов*, Г.*Габдерәхимов*, Г.*Сөләйманов* һ.б. укый. Шәкертләрнең шактый өлеше казакълардан тора. Барлык мәдрәсәләр 1920 еллар башында ябыла.

*Әд.:* Фәхретдинов Р. Сәид шәһәре. К., 1897; Искандаров А., Искандаров Р. Сеитов посад: Очерки по истории Оренбургской (Татарской) Каргалы. К., 2005.

**СӘЕТБАТТА́ЛОВ** Миңлегәрәй Ситдыйк улы (? – ?), Минзәлә сәүдәгәре, хәйрияче. Мөлкәте 100 мең сумга бәяләнә, 1 нче гильдия сәүдәгәре, Чаллы, Рыбинск, С.-Петербург шәһәрләрендә ашлык һәм чәй б-н сәүдә итә. Чаллы шәһәрендә — пристань, Минзәләдә, Хуҗамәт, Шуган авылларында йортлар хуҗасы. 1884 елда Минзәлә шәһәре мөселманнары җәмгыятенә мәчет төзү өчен җир бүләк итә. 1907 дә Уфа губернасы Минзәлә өязе Сәмәкәй авылында таш мәчет салдыра.

*Р.Р.Салихов.*

**СӘЕТБАТТА́ЛОВ** Хәйдәр Гозәер улы (3.11.1923, хәзер Казакъстан Респ-касының Тургай өлкәсе Кустанай ш.), график. 1954 елда Мәскәү читтән торып уку полиграфия ин-тын тәмамлый. 1946–48 дә Кустанайда сәнгать остаханәсе мөдире. 1948 дән Ленинградта, СССР ФАнең Рус әдәбияты ин-тында (Пушкин Йорты) рәссам булып эшли, 1957–62 дә РСФСР Сәнгать фондындагы Ленинград бүлегендә музыка нәшриятының сәнгать мөхәррире, 1962–64 тә графика ком-тының баш рәссамы була, 1965–93 тә В.И.Мухина исем. Югары сәнгать-сәнәгать уч-щесендә укыта. Бөек Ватан сугышында катнаша.

1960 елларның 2 нче яртысында Сов. Союзы Геройлары портретлары сериясен башкара. Документаль һәм тарихи портрет жанрында эшли: карандаш б-н натурадан һәм фоторәсемнәрдән карап ясый. Аның модельләре — сәясәт эшлеклеләре, хәрбиләр, фән һәм мәдәният вәкилләре: «Бөек Ватан сугышы ветераны Д.А.Әминов» (1992), «Бөек Ватан сугышы ветераны С.А.Алекперов», «Профессор К.С.Тугеев» (икесе дә — 2005), «Л.Н.Гумилёв», «Җырчы А.Әсәдуллин», «Вице-адмирал М.Д.Искәндәров», «Музыкант Х.М.Чәнәкәев», «Гарәп теле һәм әдәбияты белгече М.Х.Зарипова» (барысы да — 2006), «Бизнес Р.Нуриев» (2007), «Академик И.Г.Ибраһимов» (2008), ш.у. «Ильфира» (рәссамның хатыны) (1990–2000), үз «Автопортрет»ы (2001).

Миккели шәһәре губернаторы чакыруы буенча, С. 1993 тән Финляндиядә яши. Фин хакимиятләре заказы буенча 1939–40 елгы совет-фин сугышы геройлары (200 дән артык портрет Миккели шәһәре галереясында саклана), Финляндиянең хәрби җитәкчесе һәм президенты К.Маннергейм (1996), генерал У.Каркайнен (1998) һ.б.ның портретларын эшли. 2 мең карандаш рәсемнәре Финляндия музейларында һәм шәхси тупланмаларда саклана, аларның бер өлеше С.ның 2000 дә Финляндиядә басылган «Сүзләр һәм портретлар белән Куухкуле турында. Бәйрәм китабы» исемле авторлык альбомына кертелгән.



Х.Г.Сәетбатталов. «РФ халык артисты София Александровна Ялышева портреты». Кәгазь. Карандаш. 2006.

2003–09 да С. Татарстанның дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, язучы, галим, артистлары портретлары галереясын тудыру максатында Казанга килә. Аның тарафыннан М.Шәймиев, Р.Миңнеханов, Ф.Мөхәммәтшин, Г.Сабирҗанов, М.Госманов, Ф.Галимуллин, И.Шакиров һ.б.ның, ш.у. үткәннәрнең күренекле шәхесләре — К.Фукс, Г.Тукай, С.Сәйдәшев, А.Ключарёв, Р.Яхин, Ф.Яруллин, К.Нәҗми, С.Хәким, М.Булатова һ.б.ның портретлары иҗат ителә. С. үзенең рәсемнәрен Фабриано маркалы агартылган цымользадан эшләнгән чыдам Италия кәгазендә ясый. Аның график мирасына 5 меңнән артык рәсем керә.

Ленинградтагы шәһәр һәм өлкә күргәзмәләрендә (1960 тан), Лейпцигтагы халыкара китап күргәзмәләрендә (ГДР, 1960) катнаша. Шәхси күргәзмәләре Корсунь-Шевченко (Украина, 1982–83), Ленинград шәһәрләрендә һәм Ленинград өлкәсендә (1983–85, 8 күргәзмә); Финляндиядә (1993–2001); Казанда (2004, 2006, 2012) уздырыла.

С.ның әсәрләре 100 дән артык музейда, иң зур тупланмалары Хельсинкиның сынлы сәнгать музеенда, Финляндия шәһәрләре музейларында урын алган; 100 дән артык портреты ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеена бүләк ителгән. С. һәм аның хатынының портретлары Финляндиянең Милли сәнгать музеенда урнаштырылган. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр, Финляндиянең Почётлы Алтын тамгасы, РФ Югары белем министрлыгының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Петербургские татары в Великой Отечественной войне. СПб., 2005; Учёные Татарского государственного гуманитарного университета. К., 2008; Татарская община Санкт-Петербурга и Ленинградской области. Портретная галерея. СПб., 2008 (автордаш).

*Әд.:* Искусство оформления книги. Работы Ленинградских художников 1917–1964: Альбом. Л., 1966. *Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**СӘЕТГАЛИ́ЕВ** Сәхипгәрәй Сәетгали улы (6.2.1894, Уфа ш. — 10.11.1939), дәүләт эшлеклесе. 1915 елга кадәр Уфа, Чиләбе, Омск, Саратов, Оренбург һ.б. шәһәрләрдә эшли. 1915 тә Россия армиясенә хәрби хезмәткә алына, 126 нчы запастагы пехота полкының сапёрлык эше инструкторы. 1916 дан революцион эшчәнлектә катнаша. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң полк советы әгъзасы, Екатеринбург Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларының Казан советы әгъзасы, мөселман гаскәриләренең гарнизон ком-ты рәисе. 1917 нең июль аенда мөселман гаскәриләренең 1 нче корылтаен оештыруны башлап йөрүче (Екатеринбург); Урал өлкәсенең мөселман хәрби советы рәисе. 2 нче Бөтенсоюз мөселман хәрби корылтаенда катнашучы (Казан, 1918). 1918–19 да *Казан Совет Эшче-Крәстиян Республикасында* милләтләр эше буенча комиссар, РКП(б)ның Уфа губерна ком-тында Татар-башкорт бюросы әгъзасы, Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлеге каршында мөселман хәрби-сәяси курслар укытучысы. 1919 ның ноябрендә Шәрекъ халыклары коммунистлар оешмаларының (КОНВ) 2 нче корылтае делегаты, РКП(б)ның ҮК каршындагы КОНВның Үзәк бюросы рәисе итеп сайлана. 1920 нең гыйнварында Эчке эшләр халык комиссариаты каршындагы ТАССР чикләрен өйрәнү һәм билгеләү комиссиясе составына, 1920 нең май аенда ТАССР оештыру мәсьәләсе буенча хакимият комиссиясе составына кертелә. 1920–21 дә Вакытлы революцион ком-т, соңрак ТАССР ХКСның беренче составы рәисе. С. дәверендә «Татар телен республика совет учреждениеләренең эш кәгазьләренә кертү турында» Декреты кабул ителә (1921). 1921–24 тә Кырым АССРның ХКС рәисе, 1923 тә милли респ-калар җаваплы хезмәткәрләре катнашындагы РКП(б) *ҮКның дүртенче киңәшмәсендә* була. 1924–26 да Эшче-крәстиян инспекциясе Үзәк контроль комиссиясенең финанс-бюджет һәм а.х. секцияләре җитәкчесе. 1926–28 дә Коммунистлар академиясе каршындагы курсларда укый. 1928–31 дә Бөтенсоюз «Тепло и сила» тресты җитәкчесе урынбасары, җитәкчесе. 1931–33 тә СССРның Хезмәт халык комис-ты коллегиясе әгъзасы. 1933–37 дә Рязань–Урал тимер юлы Саратов бүлекчәсенең сәясәт бүлеге башлыгы. Бөтенсоюз ҮБК һәм СССР ҮБК әгъзасы. Репрессияләр чоры корбаны. Казандагы бер урам һәм мәдәният йорты С. исеме б-н атала.

*Әд.:* С а й д а ш е в а М.А. Саид-Галиев Сахибгарей // Борцы за счастье народное. К., 1967. *М.А.Сәйдәшева.*

**СӘЕТГӘРӘ́ЕВ** Рәүф Әхмәт улы (2.2.1925, Казан — 27.5.2003, шунда ук), генерал-майор (1976). Байкал арьягы пехотачылар хәрби уч-щесен (Чита ш., 1944), СССР МС каршындагы Дәүләт иминлеге ком-тының Ф.Э.Дзержинский исем. Югары мәктәбен (Мәскәү, 1964), СССР Дәүләт иминлеге ком-ты югары чик сакчылары курсларын (Мәскәү, 1972) тәмамлый. 1936–39 елларда Лаеш, Балык Бистәсе авылларында яши; 1939–42 дә Кадала, Наклонный посёлокларында (Чита өлкәсе) электромеханика остаханәләрендә токарь булып эшли. 1943 тән Кызыл Армия сафларында. 1944–49 да Байкал арьягы эчке эшләр халык комис-тының 29 нчы Минусинск кавалерия чик сакчылары отрядында чик буе заставасы башлыгы ярдәмчесе һәм башлыгы урынбасары. 1950–51 дә 64 нче Мангут (Чита өлкәсе) чик сакчылары отрядының «Верхний Ульгун» тикшерү-үткәрү пункты өлкән тикшерүчесе. 1951–52 дә совет-кытай чигендәге Даурия чик сакчылары отрядының Новоцурухайтуй чик буе комендатурасы разведка подразделениесендә. 1953–58 дә Балтыйк буе чик сакчылары округындагы 106 нчы Таллин чик буе отряды разведка бүлегенең өлкән оператив вәкиле. 1958–71 дә Кавказ арты чик сакчылары округындагы Нахичевань, Пришиб һәм Гадрут чик буе отрядлары разведка подразделениеләрендә хезмәт итә. 1972–73 тә Ерак Көнчыгыш чик сакчылары округында разведка бүлеге башлыгы урынбасары. 1973–79 да Көнчыгыш чик сакчылары округында разведка гаскәрләре башлыгы урынбасары. 1979–80 дә Әфганстан Демократик Респ-касы оператив чараларында катнаша. 1979–83 тә СССР Дәүләт иминлеге ком-тының Югары чик сакчылары командирлары курсларында укыту үзәге башлыгы (Владимир ш.). 1983 тән запаста, 1984 тә Казанга күчеп кайта. 1984–91 дә «Союзнефтепромхим» фәнни җитештерү берләшмәсенең Беренче бүлеге башлыгы. 1984–96 да ТР Дәүләт иминлеге ком-тының ветераннар советы рәисе. 1997–2001 дә ТРның Сугыш һәм хәрби хезмәт ветераннары ком-ты рәисе. 2000 дә Мәскәүдә Җиңү Парадында катнаша. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, Дуслык, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. *М.З.Хәбибуллин.*

**СӘЕТКУ́ЛОВ** Владимир Гыйльман улы (15.2.1936, Уфа ш.), радиоэлектроника өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1987), проф. (1990), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1984). 1960 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый. 1960–88 дә Технология һәм хезмәтне оештыру фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында эшли, баш фәнни хезмәткәр (1986 дан). 1988 дән Казан техник ун-тында, микроэлектрон аппаратуралар конструкцияләү һәм җитештерү каф. профессоры.



С.С. Сәетгалиев.



Г.С.Сәетов.

Хезмәтләре очкыч аппаратлар һәм двигательләр җитештерү һәм эксплуатацияләү барышында зыянсыз контроль ясый торган электрон чараларга карый. С. двигательләр һәм катлаулы формалы детальләргә ультратавыш контроле алымнарының теоретик нигезләрен эшли. Нефть чыгарганда катлам басымын саклау өчен кудырыла торган судагы нефть һәм эленмә кисәкчекләр күләмен контрольдә тоту; газ турбиналы двигатель калаклары ресурсын ультратавыш б-н бәяләү мәсьәләләрен хәл итә. С. тәкъдим иткән приборлар, автоматлаштырылган системалар һәм роботлы комплекслар авиация һәм нефть-газ чыгару сәнәгате пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 43 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. «Почёт билгесе» ордены; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсы медальләре б-н бүләкләнә. СССРның спорт остасы (1958, байдаркада йөзү).

Х е з м.: Исследование погрешности импульсных толщиномеров с совмещённым преобразователем при контроле клиновидных слоёв. М., 1975 (автордаш); Контроль толщины стенок клиновидных профилей импульсными толщиномерами с трёхэлементным преобразователем. М., 1977 (автордаш); Основы проектирования электронных средств. К., 2008 (автордаш).

**СӘЕ́ТОВ** Габделхәй Сәет улы (3.4.1924, БАССРның Балтач р-ны Текән а. — 27.7.2000, БРның Тәтешле р-ны Чорголды а.), Сов. Союзы Герое (31.5.1945), сержант. Тәтешле р-нының «Спартак» к-зында эшли. 1942 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 988 нче укчы полкта (5 нче удар армиянең 230 нчы укчы дивизиясе), взвод командиры ярдәмчесе (разведчик-минамётчы). 4 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Донбасс (1943), Мелитополь (1943) һәм Варшава-Познань (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Разведка операцияләре барышында «тел»не, төркем б-н штабны, немец генералын һәм дошманның оператив карталарын кулга төшерә. Берлин тирәсендәге Руммельсбургер күле янында Шпрее елгасын кичеп чыкканда батырлык күрсәтә: 1945 нең 24 апрель төнендә беренчеләрдән булып елганы кичә һәм көнбатыш ярда плацдармны яулап ала; взвод, дошман оборонасын өзеп, аны Берлинның Трептов р-нына таба кысрыклый башлый. Сафтан чыккан командирны алыштырып, С. подразделение

б-н җитәкчелекне үз өстенә ала, дошманның берничә контрһөҗүмен кире кайтарып, плацдармны тотып тора һәм батальон подразделениеләренә елганы кичеп чыгуны тәэмин итә. Сугыштан соң Киров исем. к-зда (Тәтешле р-ны) эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Югары Тәтешле авылының бер урамы С. исеме б-н атала.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СӘЕ́ТОВ** Илдар Хәсән улы (29.7.1952, Псков өлкәсе Печоры ш.), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1996), проф. (1999). 1975 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, машиналар төзелешендә мәгълүмат технологияләре каф. мөдире (1997 дән), 2005 тән Казан энергетика ун-ты проректоры. Хезмәтләре деформацияләнгән каты җисем механикасына, дифференциаль геометриягә һәм өслекләр теориясенә карый. С. ирекле өслектә кәкре сызыклар б-н чикләнгән катлаулы өлкәне параметрлау алымын; механиканың ике үлчәнешле кырый мәсьәләләрен якынча чишүнең югары төгәллектәге интеграль-проекцион алымын; күпкатламлы сүрүләрнең индивидуаль координата системалары параметрларын аналитик килештерү алымын; бериш булмаган катлаулы геометрик катламнардан торучы күпкатламлы сүрүләрнең катнаш дискрет-структур теориясен эшли. Математик физиканың бүленгән хисап тирәлекләрендәге күп үлчәнешле мәсьәләләрен параллель чишү өчен алгоритмнар һәм программа-аппарат чараларын төзи. ТР ФАнең Х.М.Мөштәри исем. бүләге лауреаты (1995).

Х е з м.: Вычислительная геометрия в задачах механики оболочек. М., 1989 (автордаш); Интегрально-проекционный метод построения сеточных схем для решения двумерных линейных краевых задач теории оболочек // Тр. 15 Всесоюз. конф. по теории оболочек и пластин. К., 1990 (автордаш); Комбинированная математическая модель слоистых оболочек сложной геометрии // Тр. 16 Междунар. конф. по теории оболочек и пластин. Н.Новгород, 1994 (автордаш).

**СӘЕ́ТОВ** Садыйк (? — ?), Е.И.*Пугачёв* көрәштәше. Оренбург төбәгендәге Каргалы бистәсендә яши. *Крәстияннәр кузгалышы* (1773–75) вакытында 1773 елның октябрендә фетнәчеләргә кушыла. Е.И.Пугачёвның ышанычлы кешеләреннән берсе. 1774 нең сентябрь аенда хәбәрсез югала.

Чыг.: Пугачёвщина. М.–Л., 1929. Т. 2.


**СӘЕТХУ́ҖИН** Гайнан Рәхмәтулла улы (30.6.1937, Новосибирск ш. – 13.5.2015, АКШ), спортчы (велосипед спорты — шосседа узышу), СССРның атказ. спорт остасы (1961). Смоленск физик культура ин-тын тәмамлый. Спорт б-н 1954 елда Чиләбедә шөгыльләнә башлый, 1956 дан СССР җыелма командасы әгъзасы, тренерлары — В.М.Петров, Б.А.Садовников. СССР чемпионы (1957–71, 100 *км* га төркемле, күп көнле һәм командалы узышларда), дөнья велосипед узышында җиңүче (1962, шәхси зачётта, 1961–62, 1965–66 команда зачётларында), дөнья чемпионатында бронза медаль ала (1963, 100 *км* га команда б-н узышуда). «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**СӘЙДӘ́ШЕВ** Салих Җамалетдин улы (3.12.1900, Казан — 16.12.1954, Мәскәү, Казанда җирләнә), композитор, дирижёр, пианист, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1939), ТАССРның халык артисты (1951). Хәзерге татар проф. музыкасына нигез салучы. Башлангыч муз. белемне З.*Яруллин* җитәкчелегендә ала. С.нең проф. яктан формалашуында Казан музыка уч-щесендә фортепиано (О.М.Родзевич классы) буенча укуы зур роль уйный (1914–17). Музыкага аерым сәләте һәм проф. муз. белем алуга омтылуы б-н С. яшь вакытында ук талантлы пианист һәм инструменталь ансамбль җитәкчесе буларак киң таныла. Иҗат эшчәнлеген Казанның *Шәрекъ клубында* солист-пианист, аккомпаниатор һәм инструменталь ансамбльдә уйнаучы буларак башлый. 1917 елдан Казанда, Буада башкару, пед. һәм муз.-мәгърифәтчелек эшчәнлеге, 1919 дан, ирекле рәвештә Кызыл Армиягә кергәч, Төркестан фронтының сәяси бүлеге каршында эшчәнлек алып бара. Демобилизацияләнгәннән соң, 1920–22 дә Оренбург шәһәрендә Шәрекъ музыка мәктәбендә укый, бер үк вакытта укыта һәм берникадәр вакыт аның мөдире була. Шунда ук беренче әсәрләрен — «Озын сәфәр» җырын һәм «Татар вальсы» инструменталь әсәрен иҗат итә. 1922–48 дә (бүленеп) Татар акад. театрында музыка бүлеге мөдире һәм дирижёры булып эшли (Казан).

1920 елларның 2 нче яртысында — 1930 ның башында Татар акад. театры труппасы составында дирижёр һәм аккомпаниатор булуы (Мәскәү, Ленинград, Идел буе, Урал буе шәһәрләре, Казакъстан, Кавказ арты, Урта Азия һ.б.) һәм Татар радиосыннан һәрдаим чыгышлар ясавы С. музыкасын бөтен халык арасында популяр итә. 1929 да С. Кызыл Армиянең 11 еллыгына багышланган һәм киң танылу алган «Совет Армиясе Маршы»н яза. Шул ук елда аның музыкасы б-н респ-ка турында беренче тулы метражлы «Татарстан (Дүрт елга иле)» фильмы чыга. Режиссёры — А.Дубровский. С.нең кабатланмас моң иясе булуы, татар халык көйләре үзенчәлеге б-н берлектә үз чорына хас типик интонацияләр һәм ритмнарның табигый берлегенә ирешә белү сәләте, җырларының гомумоптимистик эмоциональ җирлектә барлыкка килүе аны танылган җыр жанры остасы итә; аларның күбесе беренче тапкыр милли театр спектакльләрендә яңгырый һәм киләчәктә мөстәкыйль яшәеш ала.



С.Ж. Сәйдәшев (1 нче рәттә сулдан 4 нче) музыкантлар һәм композиторлар арасында. 1920 еллар ахыры.



С.Ж. Сәйдәшев. 1920 еллар.

Композитор иҗат мирасының төп өлешен театр музыкасы тәшкил итә. Атаклы татар драматурглары К.Тинчурин, Ф.Бурнаш, Т.Гыйззәт б-н иҗади дуслыкта С. тарафыннан 60 тан артык спектакльгә муз. бизәлеш һәм *музыкаль драма* жанрына караган «Башмагым» (1922), «Казан сөлгесе» (1923), «Сүнгән йолдызлар» (1924) һ.б. сәхнә әсәрләре иҗат ителә. С.нең 1920 елларның 1 нче яртысында иҗат иткән беренче муз. драма әсәрләре татар халык җырларының образлы һәм шигъри эчтәлегенә нигезләнә. Аларда үзенчәлекле драматик күренешләр фонында төрле характердагы муз. жанрлы эпизодлар урын ала (биюле-хорлы күренешләр, җырлар, биюләр, инструменталь номерлар). Бу спектакльләрнең һәрберсенә хас муз. бизәлешнең төп күрсәткечен лирик характердагы аерым бер халык көенең күп мәгънәле яңгырашы билгели, ул үзенчәлекле лейтмотив сыйфатында, ш.у. вокаль һәм инструменталь номерлар нигезендә баш геройларга муз. характеристика бирә. 1920 елларның 2 нче яртысында — 1930 еллар башында муз. драма татар муз.-сәхнә сәнгатенең алдынгы жанры була. Бу чорда С. нең аеруча зур иҗади әһәмияткә ия әсәрләре — К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» (1926), «Ил» (1929), «Кандыр буе» (1932), Т.Гыйззәтнең «Наёмщик» (1928) муз. драмалары. Бу жанрга караган әсәрләр җырлар, арияләр, хорлар, ансамбльләр, увертюралар, бию сюиталарын һ.б. төрле вокаль һәм инструменталь номерларны үз эченә ала. Аларда музыка, милли сәнгатьтә беренче буларак, идея-сәнгати фикерне гәүдәләндерүдә, драматургия үсешендә һәм образлар тудыруда төп чарага әверелә.

«Зәңгәр шәл» муз. драмасы композиторга хас үзенчәлекле көй стиле тууга сәбәпче була, анда үз чоры өчен кыю яңгыраган интонацион, ритмик һәм лад новацияләре милли көйнең үзенчәлекле күренешләре б-н табигый үрелеп бара. Бу бигрәк тә баш герой Булат партиясендә ачык чагыла. Әлеге образ шул чорның муз. символлары ярдәмендә дә (күмәк җырлар һәм маршлар), ш.у. халык дастаны һәм лирикасы традицияләрендә дә төрле яклап тасвирлана. Мәйсәрә җыры һәм Булатның «Кара урман» ариясе — иң яхшы муз. номерлар. «Наёмщик» — татар сәнгатендә муз. драма жанрының аеруча үзенчәлекле үрнәге. Тарихи темага багышланган әлеге сюжетның муз. гәүдәләнеше масштаблылыгы б-н аерылып тора. Анда төп катнашучы булып крепостнойлыктан азат ителү өчен көрәшүче халык образы тора. Бу драмада шактый персонажлар төрле вокаль номерлар, барыннан да бигрәк арияләр ярдәмендә үзләренә генә хас муз. тасвирлама алалар. Вакыйгада оркестр б-н чыгыш ясала торган җентекле эшләнгән номерлар, аның нигезен тәш-

кил иткән хорлар, драма өлкәсендәге киң күләмле муз. образлы күренешләр (жанр, лирик, лирик-драматик, героик) әһәмиятле функциягә ия булалар. Инструменталь номерлар, бигрәк тә бер-берсенә капма-каршы ике хореографик сюита социаль чыгышлары б-н үк аерылып торган һәм бер-берсенә карата тискәре мөнәсәбәттә булган персонажларның, ягъни крепостной крәстияннәр б-н җәмгыятьнең өстен катлау вәкилләренең яшәү рәвешләрендәге аерманы чагылдыра. Шуларның берсе фольклор бию көйләре рухындагы үзенчәлекле номерлардан гыйбарәт, икенчесе классик балет сюитасы принцибы буенча төзелә. С. иҗатында беренче тапкыр бу әсәрдә истә калырлык муз. характеристика хатын-кыз образына бирелә. Үзара ярашкан озын татар көйләре һәм классик опера арияләре стилистикасыннан торган тәэсирле, хис-кичерешләргә бай Гөлйөзем арияләрендә баш героиняның бай рухи дөньясы чагылыш таба. «Наёмщик»та лирик вокаль номерлар (арияләр, дуэтлар) тәэсирле, әмма беренче планга чыкмый. Музыкаль күренешнең төп факторы булып халык образын киң һәм күпкырлы гәүдәләндергән хор номерлары тора. Баш герой Батырҗан арияләре б-н бергә алар драманың татар музыкасына С.нең сәхнә әсәрләре б-н килеп кергән төп муз.-образлы героик-драматик нигезен тәшкил итәләр. Монда комп. 20 йөзнең беренче унъеллыгына хас булган күмәк җыр һәм марш музыкасы интонацияләреннән һәм ритмнарыннан (актив, күтәренке, кискен ритмик көйләр һәм төгәл ритмнар) кыю файдалана. «Наёмщик»та муз. драма элементлары сизелерлек күренә: сюжет ачыла барган саен, төп персонажларны һәм коллектив образ буларак халыкны чагылдыручы лейтмотивларның интонацион үсеше күзәтелә.

1930 елларның 2 нче яртысыннан С. кайбер объектив сәбәпләр аркасында үзенең иҗади ниятләрен тулысынча тормышка ашыра алмый. Аның өчен бу еллар туганнарын, якыннарын һәм иҗатташ дусларын фаҗигале рәвештә югалту дәвере була. Бу елларда татар композиторларының яңа буыны опера, балет, симфония жанрларын актив үзләштерә, ә үз кыйммәтен әле җуймаган һәм демократик аудитория тарафыннан хупланучы муз. драма милли муз. культураның киң үсеш юлыннан читкә тайпыла. Аның формалашуы ясалма рәвештә туктатыла. Мондый шартларда С. күбрәк җыр һәм марш жанрларына игътибар бирә. Аның күмәк башкарыла торган җырлары (мәс., «Дуслык җыры», 1949, Ә.Ерикәй шигыре) интонациясе, марш ритмы, көчле динамикасы б-н аерылып тора. Композиторның саф җыр лирикасы камил булып кала: Г.Хуҗи шигыренә «Халисә» (1950), М.Садри шигыренә «Яшьлек җыры» (1949) һ.б. С.нең җыр иҗатының аеруча мөһим өлешен балалар өчен язылган җырлар тәшкил итә: С.Урайскийның «Укучылар вальсы» (1951), Г.Насрыйның «Зәңгәр күл» (1951) һ.б. җырлар. Композиторның соңгы әсәре — иҗади васыяте — М.Җәлил шигыренә язылган «Җырларым» җыры. Иҗатында 20 йөз татар проф. музыкасы формалары һәм жанрлары, эстетик критерийлары һәм стиль үзенчәлекләре формалашкан С., беренче милли классик композитор буларак, татар муз. культура тарихында аерым урын алып тора. Аның композиторлык һәм башкару иҗаты күп еллар дәвамында Татарстанның музыка сәнгатендә төп рольне уйный һәм бөтен халык мәхәббәтен казана. С.нең татар халкының сәнгатьчә фикерләү үзенчәлеге б-н аваздаш булган һәм аеруча уңайлы сәхнә формасына әверелгән муз. драма жанрына мөрәҗәгать итүе аерым әһәмияткә ия. Мондый сәхнә формасы татар муз. культурасының фольклор традицияләреннән заманча профессионализмга күчүенә этәргеч бирә. С.нең бу милли жанрга мөрәҗәгать итүе тарихи әһәмияткә һәм сәнгати нигезгә ия, чөнки мондый жанрда драматик хәрәкәт б-н табигый үрелеп барган музыка авторның идеясен һәм сәнгатьчә күзаллавын гәүдәләндерүдә аеруча мөһим чараларның берсе булып тора. Композитор, үз халкы муз. культурасының тарихи



С.Җ. Сәйдәшев иҗат итә.

тәҗрибәсен гомумиләштереп, аңа Европа һәм рус классик музыкасына хас сәнгати нормаларны, төрле халыклар музыкасында киң таралган интонацияләр һәм ритмнарны табигый рәвештә кертеп җибәрү юлларын таба. С. истә калырлык, кабатланмас көйләр тудыру остасы була. Аның иҗатында халык җырларына яңача караш, аларның мәгънәви асылына тирәнтен төшенү, ш.у. башка милләтләрнең жанр һәм стиль үзенчәлекләрен актив җәлеп итү нигезендә милли көйләрнең сыйфат ягыннан яңартылуы күзәтелә. Композитор, татар музыкасы тарихында беренче тапкыр гармоник фактура чараларын киң куллана, программалы жанр симфонизмы формаларында оркестр язмаларын (увертюралар, сюиталар һ.б.) өйрәнүгә керешә. Бу монодийлы ангемитон традицияләр өстенлек алган муз. культурада яңача фикерләү күрсәткече булып тора. Әмма, яңалык билгеләренә карамастан, С. иҗаты киң күләм тыңлаучыларга һәрвакыт аңлаешлы булып кала. Композитор татар халкының сизгер муз. аңын басым ясамыйча әкрен генә һәм әзлекле үстерә. С. әсәрләренең аңлаешлы булуы, бер үк вакытта югары сәнгати кыйммәте аларда үзенчәлекле миллилекнең һәм татар музыкасы өчен яңа күренешләрнең катлаулы, әмма табигый берлеге рәвешендә бирелүе б-н аңлатыла. Кыю новаторлык күренешләре б-н ярашкан милли музыка үзенчәлегенә тирәнтен төшенү С.кә Татарстанда композиторлык сәнгатенең алга таба үсешенә нигез салырга мөмкинлек тудыра.

С. иҗаты һәрвакыт та рәсми танылу тапмый, әмма татар халкы аны аеруча яратып тыңлый, аның әсәрләре респ-каның алдынгы башкаручылары репертуарында алыштыргысыз урын алып тора. Хәзерге вакытта композиторның күпкырлы шәхес булуы һәм аның иҗат мирасының бәяләп бетергесез әһәмияте күбрәк ачыла. С. нигез салган традицияләр Татарстанның хәзерге заман милли муз. культурасының барлык өлкәләрендә дә ачык чагылыш таба. Төп әсәрләре: муз.-сәхнә әсәрләре (муз. драмалар һәм комедияләр, драма спектакльләренә музыка): Г.Хәмиди пьесасы буенча «Һинд кызы» (1924); М.Фәйзи, Ф.Бурнаш, Г.Кутуй пьесалары буенча «Камали карт» (1925), «Галиябану», «Таһир-Зөһрә», «Яшь йөрәкләр», «Балдызкай» (барысы да — 1926); Һ.Такташ, Ф.Бурнаш пьесалары буенча «Күмелгән кораллар», «Хөсәен Мирза» (барысы да — 1927); Г.Кутуй, Ш.Камал пьесалары буенча «Калфаклылар», «Күк күгәрчен», «Ут» (барысы да — 1928); Г.Минский, А.Хәбиб-Вафа, В.Киршон, Р.Ишморат, Г.Уральский пьесалары буенча «Шлем», «Робиндар», «Җилләр шәһәре», «Данлы чор», «Утлы божра» (барысы да — 1930); Ш.Камал, Һ.Такташ пьесалары буенча «Таулар», «Камил» (барысы да — 1931); Г.Зөлкарнәй пьесасы буенча «Өермә», К.Тинчурин һәм Р.Ишморат пьесасы буенча «Тургай» (1932; В.Виноградов б-н берлектә); Ф.Бурнаш, К.Тинчурин пьесалары буенча «Лачыннар», «Булат бабай гаиләсе» (1933); С.Баттал, Т.Гыйззәт, Г.Минский, Х.Фәтхуллин пьесалары буенча «Сынау», «Бишбүләк», «Гөлчәчәк», «Күзләр» (1939); Г.Камал пьесасы буенча «Хафизәләм иркәм» (1943; М.Юдин б-н берлектә); Т.Гыйззәт пьесасы буенча «Изге әманәт» (1944); Н.Исәнбәт пьесасы буенча «Мулланур Вахитов», Т.Гыйззәт пьесасы буенча «Чын мәхәббәт» (1948), «Алсу таң» (1950); Г.Насрый пьесасы буенча «Кадерле минутлар» (1953) һ.б.; Г.Таһиров либреттосына «Гөлнара» (1950, куелмый); инструменталь әсәрләр: «Н.Сакаев истәлегенә марш» (1927), «Ватан» маршы (1943) һ.б.; «Озын сәфәр» (1922, текст авторы билгесез), Г.Кутуй шигыренә «Алга» (1941), Т.Гыйззәт шигыренә «Бүген бәйрәм» (1945), Г.Насрый шигыренә «Совет Татарстаны» (1950) җырлары; балалар өчен М.Садри шигыренә «Мәскәү» (1947), Ш.Маннур шигыренә «Яшь туристлар»; «Салют бирәбез», «Бал корты» (1950) һ.б. җырлар. 2000–04 елларда С.нең 3 томда әсәрләр җыентыгы басыла.


*Әд.:* С ә й ф у л л и н Р. Салих Сәйдәшев — татар профессиональ музыкасына нигез салучы // Халыкка багышланган тормыш. К., 2012; Г и р ш м а н Я.М. Салих Сайдашев. К., 1956; Салих Сайдашев. Материалы и воспоминания. К., 1970; Воспоминания о Салихе Сайдашеве. К., 1980; С а л и т о в а Ф.Ш. Музыкальные драмы Салиха Сайдашева. К., 1988; ш у л у к. Творческое сотрудничество драматурга Тинчурина и композитора Сайдашева // Традиции и новаторство в творчестве К.Тинчурина. К., 1990; ш у л у к. Салих Сайдашев: Жизненный и творческий путь. К., 2011; С а и н о в а - А х м е р о в а Д.З. Салих Сайдашев: страницы жизни и творчества. К., 1999; Тематическая подборка, посвящённая 100-летию С.З.Сай-

дашева // Казань. 2000. № 12; Век Салиха Сайдашева: Межвуз. сб. К., 2000; Ш а м о в С. Салих Сайдашев. Драма жизни. К., 2010; ш у л у к. Салих Сайдашев: величие и трагизм личности. К., 2012. *Ф.Ш.Салитова.*

**СӘЙДӘ́ШЕВ САЛИ́Х МУЗЕЕ́**, Казанда. ТАССР МС карары нигезендә 1988 елның 23 февраленнән ТАССРның берләштерелгән Дәүләт музее (хәзер ТРның Милли музее) ф-лы буларак оештырыла. 1993 нең 25 июнендә ачыла. Элеккеге Татар акад. театры (хәзер Татар драма һәм комедия театры бинасы) ишегалдындагы аерым кечкенә йортта урнашкан (20 йөз башы; архит-ра истәлеге), 1930–54 тә анда композитор С.Ж.*Сәйдәшев* яши. Экспозиция мәйданы 181 *м*². Фондта 794 саклау берәмлеге. Музей экспозициясе фәнни хезмәткәрләр Я.С.Шәмсетдинов, Ф.Ш.Салитова, Д.З.Саинова, А.З.Ханина, А.Г.Соколова, Э.Р.Хәмидуллина тарафыннан оештырыла, рәссамнар А.П.Леухин, В.А.Нестеренко ТР ФАнең мөхбир әгъзасы Б.М.Галиев җитәкчелегендәге «Прометей» махсус КБ б-н бергә бизиләр. Экспозиция икенче катның алты залында урнашкан. Аның үзәге — «ак бүлмә», андагы экспонатлар (19 йөз ахыры — 20 йөз башы немец фирмасы «Georg Hoffmann» пианиносы, винтлы түгәрәк урындык, дирижёр таягыннан башка) рухи яктылык, чисталыкны гәүдәләндерүче ак төскә буялган. Экспозициянең башка заллары композиторның тормышы һәм иҗаты (бала чагы, музыка укытучылары, беренче уңышлары һәм югалтулары, гадәттән тыш югары үсешкә һәм иҗади өлгергәнлеккә ирешүе, гомеренең соңгы еллары һәм үлгәннән соңгы даны) б-н таныштыра. Экспонатлар арасында С.Сәйдәшевнең әнисеннән калган 19 йөз ахыры трельяжы, композиторның беренче укучысы Фатыйма-Зөһрә Солтанованың кулдан язылган көндәлеге (1919), композиторның үлгәннән соң скульп. С.С.*Ахун* тарафыннан алынган маскасы бар. Экспозициянең аеруча истә калырлык элементлары — С.Сәйдәшевнең «Зәңгәр шәл», «Наёмщик», «Совет Армиясе Маршы», «Әдрән диңгез» һ.б. киң танылган әсәрләренә багышланган инсталляцияләр.

Музейның муз. салонында һәрдаим презентацияләр, композиторлар һәм башкаручыларның концертлары, танылган сәнгать һәм мәдәният эшлеклеләренең истәлегенә, мөһим даталарга багышланган иҗат кичәләре үткәрелә. Ел саен декабрь аенда С.Сәйдәшевнең туган көненә (3 декабрь) һәм аны искә алу көненә (16 декабрь) багышланган муз. очрашулар традициягә әверелә.

*Әд.:* Музей Салиха Сайдашева: Буклет. К., 2002; Все музеи Казани: Справ.-путеводитель. К., 2004.



Казанда Салих Сәйдәшев музее. «Ак бүлмә» экспозициясе фрагменты.

**СӘЙДӘ́ШЕВ САЛИ́Х ҺӘЙКӘЛЕ́**, Казанда. С.*Сәйдәшев* һәйкәле проектына 1988 елда композиторның 100 еллык юбилее уңаеннан конкурс игълан ителә. 2000, 2001 дә тагын 2 конкурс уза. Җиңүчесе М.М.*Гасыймов* була. Казанның эксперименталь нәфис кою з-дында аның моделе буенча бакыр скульптура коела. Һәйкәл 2005 нең 12 августында ачыла. Арх. Г.А.Бакулин һәйкәлне Татар гуманитар пед. ун-тының фасады 18 колонна б-н бизәлгән ярымтүгәрәк бинасы каршындагы мәйданның үзәгенә урнаштыра. Скульптураның биеклеге — 3,5 *м*, гранит постаменты — 2,5 *м*. Композитор кулында дирижёр таягы б-н, концерт костюмында бөтен буена



Салих Сәйдәшев һәйкәле. Скульпторы М.М.Гасыймов, архитекторы Г.А.Бакулин. 2005.

сурәтләнә. Уң терсәге б-н каннелюрлы импровизацияләнгән тәбәнәк колоннага таянган. Һәйкәлне әйләндереп алган балюстрада композициясе ноталар кую өчен пюпитр (аскуйма) б-н төгәлләнә.

С.Сәйдәшевнең скульптура һәйкәле б-н архит-ра ансамбле, Г.Тукай һәйкәле б-н скверны, Казанның меңьеллыгы паркын, Татар акад. театрын һәм милли архит-ралы тыюлы зонасын — элеккеге Иске Татар бистәсен кертеп, Казанның тарихи-мәдәни үзгендә мәдәни манзара хасил итә.

*А.В.Гарзавина.*

**СӘЙДӘ́ШЕВА** Земфира Нурмөхәммәт кызы (20.5.1938, Казан), музыка белгече, фольклорчы, педагог, сәнгать фән. д-ры (1998), проф. (2000), ТАССР һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1989, 2002). Композиторлар берлеге әгъзасы (1972). 1966 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1957–66 да Казан, Буада балалар музыка мәктәбе укытучысы, 1970–77 дә СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тының фәнни хезмәткәре. 1977 дән Казан консерваториясендә укыта. С.ның төп фәнни кызыксынулар өлкәсе татар халык һәм проф. музыкасын өйрәнү б-н бәйле. Аның публицистик язмалары Татарстанның хәзерге муз. культура үсеше проблемаларына багышлана.

Х е з м.: Татарская советская песня. К., 1984; В мире татарской музыки. К., 1995; Современная татарская бытовая песня. К., 1997; Татарская музыкальная этнография. К., 2007; Татарская музыка: история и современность. К., 2008.

*Әд.:* М ө с л и м о в а Л. Әтидән калган мирас // Сөембикә. 1998. № 5.

*Ф.Ш.Салитова.*

**СӘЙДӘ́ШЕВЛӘР**, Казан сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре, җәмәгать эшлеклеләре. **Әхмәтҗан Яхья улы** (16.7.1840, Казан губ., Лаеш өязе Татар Кабаны а. — 8.5.1912, Казан), мулла гаиләсендә туа. Апанай мәдрәсәсендә (Казан), Вятка губернасының Малмыж өязе Мәчкәрә авылы мәдрәсәсендә укый. 1860 елларда Казан сәүдәгәре М.Г.Госмановта приказчик булып эшли. 1875 тән — 2 нче, 1888 дән 1 нче гильдия сәүдәгәр. 1870 тә Казанда Чәй һәм күн әйберләр сәүдә йорты ача. Шәһәрнең Зур Проломная (хәзерге Бауман), Воскресенская (хәзерге Кремль) урамнарында, Печән базарында чәй кибетләре хуҗасы. 1890 да алпавыт А.Желтухин варисларыннан Казан губернасының Царёвококшайск өязе Воскресенский һәм Петровский авылларында пыяла-скипидар з-ды сатып ала. Заводта шәраб, аракы, минераль су өчен шешәләр һәм даруханәләр өчен төрле пыяла савытлар җитештерелә. Заводта 2 мең кеше эшли, елына 2 млн.га якын берәмлек пыяла савыт җитештерелә. Завод продукциясе Мәскәү, Идел буе, Себер, Кавказ, Германиягә җибәрелә. 1894 тә Б.Субаев б-н берлектә «Ә.Сәйдәшев, аның уллары һәм Б.Субаев сәүдә-сәнәгать ширкәте»н оештыра. Ширкәт пыяла, чәй һәм мех әйберләр б-н сәүдә итә, төп капиталы 500 мең сумга җитә. Әхмәтҗан С. акчасына Петровский авылында янгыннан соң чиркәү торгызыла, авыл завод уч-щесе һәм даруханә аның карамагында була. 20 йөз башында С., базар шартлары начарлану һәм финанс яктан авырлыклар туу сәбәпле, пыяла әйберләр җитештерүне туктатып, Казанда прәннек һәм татлы әйберләр җитештерә башлый. Казанда сәүдәгәрләр җәмгыяте әгъзасы (1901–05). 1873 тән Казан шәһәр думасы, өяз земство җыены гласные, мөселманнар төркеме җитәкчесе. Әхмәтҗан С. ярдәме б-н Казанның Татар бистәсе урамнарына таш салына, электр уты, су үткәрелә, мед. хезмәте күрсәтү яхшыртыла. «*Иттифакъ әл-мөслимин*» партиясен оештыруга һәм эшчәнлегенә зур өлеш кертә, 1905 тә — Сәүдә-сәнәгать партиясе әгъзасы. Татар җәмгыятенең сәяси тормышында актив катнаша; мөселман руханилары өчен мәгариф цензы турындагы 1888 елның 12 июль законын тәнкыйтьли, 1904 тә Өйләнешү турында яңа канун кабул итү мәсьәләсен хәл итү максаты б-н С.-Петербургка килгән Казан делегациясе әгъзасы, Мөфтият эшчәнлеген активлаштыру таләбе б-н чыгыш ясый. Рус-татар мәктәпләре ачылуга ярдәм күрсәтә, Казандагы кайбер татар уч-щеләре попечителе була. «*Мөхәммәдия*» мәдрәсәсенең яңа бинасы төзелешенә акчалата булышлык итә (1885–86). «*Бәянелхак*» г-тасы нашире һәм мөхәррире. Оренбург Мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие

М.М.Солтановның 25 еллык хезмәте уңаеннан уздырылган бәйрәм мәҗлесендә катнаша (1911). Ятимнәр йортларының Казан губерна попечительлеге шәрәфле әгъзасы, Төрмәләр турында губерна попечительләр ком-ты директоры итеп сайлана. Казанда 35 кешегә исәпләнгән вакытлыча төнге балалар йортын үз акчасына тота, аның башлангычы б-н 1895 тә Казан губернасында 15 кешегә исәпләнгән беренче мөселман картлар йорты ачыла. *Казан шәһәре мөселманнары хәйрия җәмгыяте* идарәсен оештыручыларның берсе һәм әгъзасы. Актив эшчәнлеге һәм татар җәмгыяте тормышына йогынтысы өчен Әхмәтҗан С.не исән чакта ук «Казанның татар губернаторы» дип атыйлар. **Мөхәммәтҗан Әхмәтҗан улы** (3.1.1865, Татар Кабаны а. — 9.4.1914, Казан), Казанның Апанай мәдрәсәсендә укый. 1885 тән «Ә.Сәйдәшев, аның уллары һәм Б.Субаев сәүдә-сәнәгать ширкәте» директоры. 1888 дән «Б.Субаев, И.Борнаев һәм М.Сәйдәшев» сәүдә йорты милектәше (төп капиталы 300 мең сум тәшкил итә). Ширкәт мех әйберләр җитештерү һәм сәүдәсе б-н шөгыльләнә. Соңрак «Б.Субаев һәм М.Сәйдәшевнең мех әйберләр җитештерү һәм сәүдәсе» ширкәте хуҗаларының берсе (1897 гә кадәр), «М.К.Еврампова һәм К° сәүдә йорты»ның милектәше һәм идарәчесе (1907 дән). Казан шәһәр думасы, өяз земство җыены гласные. Шәһәр думасында училище, инвентарь, урман, болын һ.б. комиссияләр әгъзасы; 1911 дә Иске татар бистәсендә ике төп урамга асфальт җәйдерә. Комиссия тырышлыгы б-н 1907 дә татар авылларында земство акчасына яңа типтагы мәктәпләр оештырырга рөхсәт бирә торган карарлар кабул ителә. Алга баручылар (прогрессистлар) партиясеннән 4 нче шәһәр думасына сайлау кампаниясендә катнаша (1912, сайланмый). «Бәянелхак» г-тасы мөхәррире (1906–14), 1907 дә С.Алкиннан «*Казан мөхбире*» г-тасын нәшер итү хокукын сатып ала, аны 1911 гә кадәр чыгара. Бу газеталарда татар халкының көндәлек тормышын, Казанның үсеш мәсьәләләрен, халык мәгарифе торышын, шәһәр думасы хисапларын яктырткан мәкаләләр бастыра. 1907 нең июнь аенда әтисе б-н берлектә «*Бәянелхак*» басмаханәсен ача, анда гомуми тиражы 220 мең экз.дан артык 75 исемдә китап нәшер ителә. С. бөтен Россия мөселманнары арасында таратылган иллюстрацияләнгән «Мәгълүмат» сәүдә-сәнәгать адрес-календаре чыгаралар. Казан шәһәре ярлы мөселманнарына ярдәм итү җәмгыяте идарәсенең рәисе урынбасары.

*Әд.:* Мухамадеева Л.А., Салихов Р.Р. Автобиография Казанского купца Ахметзяна Сайдашева // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2007. № 1; Алиев И., Идрисова Р. Усадьба купца Ахметзяна Сайдашева // Дворянское гнездо. 2007. № 4; Мухамадеева Л.А. Промышленная деятельность Сайдашевых // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2008. № 2.

**СӘЙДУКО́В** Нигъмәтулла Карымшак улы (18.10.1819, Тубыл губ., Төмән өязе Ямбай а. — 1901, шунда ук), эшмәкәр, җәмәгать эшлеклесе. Чыгышы б-н крәстияннәрдән (себер бохаралылары). Туганнары Рәхмәтулла һәм Хәбибулла б-н мех, тире, галантерея әйберләре сату б-н шөгыльләнә, Төмәндә 1 нче гильдия сәүдәгәр була. 1860 еллар ахырында хаҗ кыла. Үз акчасына Ямбай авылында 2 таш мәчет салдыра, алар хәзергә кадәр сакланган һәм архит-ра истәлеге булып саналалар, Тубыл губернасы авылларында 10 лап мәчет салдыра. 1871 дән Ямбай авылы мәдрәсәсен тотарга бик күп акча бирә, тора-бара бу мәдрәсә Көнбатыш Себердә дини белем бирү буенча зур мөселман үзәгенә әверелә. 19 йөз ахырыннан анда укыту яңа алымлы «Мөхәммәдия» һәм «Хөсәения» мәдрәсәләре үрнәгендә алып барыла; 3 таш бина төзелә, зур китапханә булдырыла. 19 йөз ахырында С. акчасына Ямбай авылында татар кыз балалар мәктәбе ачыла. 1917 гә кадәр мәдрәсә һәм мәктәп, башлыча, С.ның мирас итеп калдырган акчасына тотыла.

*Әд.:* Фәйзрахманов Г.Л. Сайдуковлар // Нация. Эпоха. Личность. К., 2008; Шулук. История татар Западной Сибири с древнейших времён до начала XX века. К., 2007.

**СӘЙРА́НОВ** Садыйк Вилдан улы (15.5.1917, БАССРның Бүздәк р-ны Сыртланово а. — 21.10.1976, БАССРның Ишембай ш.), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), гв. лейтенанты. 1937–38 елларда БАССРның Мәләвез р-ны «Урал» к-зында шофёр булып эшли. 1938–40 та һәм 1941 дән Кызыл Армия сафларында. Халхин-Гол елгасы буенда япон милитаристларына каршы сугышта катнаша (1939). 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 12 нче гв. укчы полкның взвод командиры (11 нче гв. армиясенең 5 нче гв. укчы дивизиясе). Көнбатыш, Брянск һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында, Брянск (1943), Белоруссия (1944), Көнчыгыш Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Мяркине авылыннан (Литва ССР Варена р-ны) төньяктарак Неман елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: 1944 нең 14 июлендә беренчеләрдән булып елганы кичеп чыга, плацдармны яулап ала һәм ярдәмгә җибәрелгән сугышчылар килгәнче аны саклап тора. 1945 тә демобилизацияләнә. Ишембай шәһәрендә яши. «Ишембайнефть» һәм Ишембай икмәк комб-тында парторг, «Октябрьнең 19 еллыгы» артеле рәисе, Ишембай шәһәр азык-төлек сәүдә идарәсе директоры, «Центроспецстрой» трестының СУ-16 тәэминат бүлеге башлыгы, Себерне үзләштерү өчен эшче көчләр туплау бүлеге вәкиле, «Агыйдел» с-зында ферма мөдире, Ишембай трикотаж ф-касында адм.-хуҗалык бүлеге башлыгы, «Вторчермет» хәзерләү пунктында цех башлыгы булып эшли. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СӘЙТӘ́К** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 8 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Түбән Кама сусаклагычыннан 1,5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 187 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1680 нән рус чыганакларында Пустошь Сейтяк исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балыкчылык ятьмәсе үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе (1879 дан эшләүче миссионерлык мәктәбе җирлегендә 1913 тә ачыла), ашлык саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1343,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1838 дә — 317, 1859 да — 399, 1870 тә — 470, 1887 дә — 731, 1905 тә — 908, 1920 дә — 839, 1926 да — 802, 1938 дә — 682, 1949 да — 451, 1958 дә — 512, 1970 тә — 585, 1979 да — 401, 1989 да — 230, 2002 дә — 204 кеше.



С.В.Сәйранов.

**СӘЙФ САРАЙ́**(1321 тирәсе — 1396, Мисыр), төрки-татар шагыйре. Урта Иделдә дөньяга килә. Укуы һәм шагыйрь булып формалашуы *Сарай әл-Җәдид* шәһәре б-н бәйле. 1380 елларда Мәмлүкләр Мисырына китә, солтан сараенда хезмәт итә. С.С. мирасының бер өлеше генә, ш.и. «*Китабе Гөлестан бит-төрки*» (1391) җыентыгы кульязмасы, лирик шигырьләре һәм Мисырда Әбү ибне-Кадыйр төзегән «Ядкәрнамә» җыентыгына кергән «Сөһәйл вә Гөлдерсен» (1394) поэмасы саклана. Поэма назыйрә жанрында язылган 8 шигырьдән тора. Авторның максаты — аерым кешеләр язмышы мисалында «заман бәласе»н күрсәтү. Сюжет нигезен әсир Сөһәйл б-н җиңүче хаким Аксак Тимер кызы Гөлдерсеннең фаҗигале мәхәббәте тәшкил итә. Кыз егетне тоткынлыктан коткарып, аның б-н бергә кача, ләкин юлда сусаудан һәм ачлыктан үлә. Сөһәйл өметсезлектән үз-үзен үтерә. Поэманың бер бәйтендә болай диелә: Сөһәйлне күреп, Гөлдерсен аның ягына «Гөнәш гәрдендә йөргән мисле Йир тик» («Кояш әйләнәсендә йөргән Җир төсле») борыла. Әсәр авторы өчен дөньяның гелиоцентристик система идеясе гадәти төшенчә була (Н.Коперник ачышына кадәр 150 ел алдан).

Әсәр.: Гөлестан. Лирика. Дастан. К., 1999.

*Әд.:* Миңнегулов Х.Ю. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976; Наджип Э.Н. Тюркоязычный памятник XIV в. «Гулистан» Сейфа Сараи и его язык: В 2 ч. А.-А., 1975; Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и Восточная классика. К., 1993.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**«СӘЙФЕЛМӨЛЕ́К»**, урта гасырлардагы татар китап дастаны. «*Мең дә бер кичә*» хикәятләренең берсенә барып тоташа. Гарәп нөсхәсе нигезендә фарсы версиясе барлыкка килә. 16 йөздә үзбәк шагыйре Мәҗлиси, фарсы версиясенә таянып, төрки вариантын яза. Татар халкында гомумтөрки китап тексты нигезендә дастанның күпсанлы китап, кульяз-

ма һәм фольклор версияләре барлыкка килә һәм тарала. Дастанның баш каһарманы — хан углы Сәйфелмөлек, төшендә Сәхипҗамал исемле матур кызны күреп, аны эзләргә чыгып китә. Хан үзенең улы б-н бергә вәзирнең улын һәм 50 колны җибәрә. Барлык коллар һәм дөяләр үлеп, шактый сыналганнан соң, Сәйфелмөлек б-н вәзир улы төбендә *дию* урлаган Сәхипҗамал яши торган диңгезгә барып җитәләр. Каһарман егет, бармагында пәйда булган Сөләйман пәйгамбәрнең тылсымлы балдагы ярдәме б-н төрле катлаулы хәлләрдән чыга (балдак пәйда булу — төрки телле эпосның традицион мотивы). Сәйфелмөлек диюне үтерә, Сәхипҗамал үзен коткаручыга гашыйк була. Әмма аның атасы — җеннәр патшасы — кызын кешеләр дөньясыннан булган егеткә бирәсе килми. Төп каһарман патшаның мәкерлелеге аркасында һәлак була. Егетнең үлемен күтәрә алмыйча, Сәхипҗамал үз-үзенә кул сала (фаҗигале тәмамлану урта гасырлар төрки-татар дастан эпосына хас). Дастан версияләре Себер һәм Әстерхан татарлары, башкортлар һәм Кавказ халыклары арасында таралган.

Беренче тапкыр дастан 20 йөз башында нәшер ителә. ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының фольклор һәм музыка фондларында дастанның ТР, Мордва Респ-касында, Горький (хәзер Түбән Новгород), Новосибирск, Омск, Пенза, Төмән, Чиләбе өлкәләрендә язып алынган 9 варианты бар. «С.» дастанын өйрәнү б-н М.И.Әхмәтҗанов шөгыльләнә.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Дастаннар. К., 1984; «Сәйфелмөлек китабы» // Р ә м и И., Д а у т о в Р. Әдәби сүзлек. К., 2001.

*Ф.И.Урманчеев.*

**СӘЙФЕ́Л-МӨЛЕ́КОВ** Фәрит Мостафа улы (19.11.1930, Ташкент ш. – 4.6.2016, Мәскәү), халыкара журналист, режиссёр, РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1995). Әнисе ягыннан сәүдәгәр Яушевлар нәселеннән. Мәскәү көнчыгышны өйрәнү ин-ты Якын Көнчыгыш ф-тының гарәп бүлеген тәмамлый (1954). Журналистлык эшчәнлеген 1953 елда «Вечерняя Москва» г-тасында башлый, 1954–57 дә «Международная жизнь» ж-лында эшли, 1957–59 да «Восточная лира» нәшриятында мөхәррир, «Современный Восток» ж-лының гарәп илләре һәм Африка бүлеге мөхәррире, 1959–62 дә СССР МС каршындагы радиотапшырулар һәм телевидение ком-тында. 1962–63 тә СССР Дәүләт телерадиосының «Соңгы хәбәрләр» («Последние известия») редакциясендә халыкара мәгълүмат комментаторы, 1968 дә СССРның эчке радиотапшырулар төп пропаганда редакциясендә халыкара бүлекнең баш мөхәррире урынбасары. 1968–74 тә Ливанда Совет радио һәм телевидениесенең хәбәрчеләр пункты мөдире (эшчәнлек өлкәсенә Сүрия, Иордания, Кипр, Гарәбстан ярымутравы илләре дә керә). 1974 тән СССРның Үзәк телевидение һәм радиотапшыруларының сәяси күзәтүчесе. 1990 нан Швейцариядә хәбәрчеләр пункты мөдире. 1992 дән «Евразия» иҗат берләшмәсе, 1993–96 да «Останкино» телекомпаниясендә «Халыкара программалар» берләшмәсе (Мәскәү) директоры. С. журналистлык иҗатының төп темасы — Якын һәм Урта Көнчыгыш илләренең хәзерге хәлен яктырту. 1965 тән Үзәк телевидениедә «Яңалыклар эстафетасы» («Эстафета новостей»), «Вакыт» («Время») программаларында чыгыш ясый башлый. Дәүләт җитәкчеләре, күренекле җәмәгать эшлеклеләреннән интервью ала, Мисыр президенты Г.А.Насер, Иордания короле Хөсәен, Палестина лидеры Я.Арафат, Сүрия президенты Х.Әсад, Әфганстан җитәкчеләре Н.М.Таракый һәм М.Нәҗибулла, Иран руханилар лидеры Хөмәйни, Куба җитәкчесе Ф.Кастро һ.б. б-н очраша. Үзәк телевидениенең 1 нче каналындагы «Бүгенге дөньяда» («Сегодня в мире») программасын оештыручыларның берсе һәм даими алып баручысы, аның төп халыкара программаларында чыгыш ясый. Очерк һәм мәкаләләре Россиянең әйдәп баручы көндәлек матбугатында басыла, «Гыйрак республикасының барлыкка килүе» («Рождение Иракской республики», М., 1958), «Гыйрак бүген һәм иртәгә» («Ирак сегодня и завтра», М., 1960), «Африкада Португалия колонияләре» («Португальские колонии в Африке», М., 1961) һ.б. китаплар авторы. Халыкара темага кагылышлы 30 дан артык публицистик һәм документаль фильм төшерә. «Алар ирек яуладылар. Алжир хроникасы» («Они завоевали свободу. Хроника Алжира»), «Якын Көнчыгыш: сынаулар вакыты» («Ближний Восток: время испытаний») телефильмнары сценарийлары өчен РСФСРның бертуган Васильевлар исем. дәүләт бүләге (1978); Әфганстан турындагы «Җир реформасы» («Земельная реформа»), «Әфганстан. Революция дәвам итә» («Афганистан. Революция продолжается»), «Апрельдә ике көн. Революция турында репортаж» («Два дня в апреле. Репортаж о революции»), «Әфганстан. Кызу кыш» («Афганистан. Жаркая зима») документаль-публицистик кино- һәм телефильмнары сериясе өчен СССР Дәүләт бүләгенә лаек була (1981). Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, Почёт орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Ф.М.Сәйфел-Мөлеков.

*Әд.:* Кто есть кто в татарской общине Москвы. М., 2001. *Г.С.Сабирҗанов.*

**СӘЙФЕТДИ́НОВ** Галимҗан Җамалетдин улы (29.1.1882, Оренбург губ. Троицк ш. — 10.9.1918, Казан), сәясәт эшлеклесе. Мәдрәсәдә, Троицкидагы өч класслы шәһәр уч-щесендә (1895–1901), Казандагы татар укытучылар мәктәбендә (1901–04) укый. 1902–03 елларда революцион түгәрәкләр әгъзасы, Х.Ямашев, Ф.Әмирхан һ.б. б-н бергә җилембасма «Республика» г-тасын чыгаруда катнаша (Казан). 1905 тә РСДРПның Казан ком-ты һәм аның пропаганда төркеме әгъзасы, татар телендә әдәбият, прокламацияләр тәрҗемә итү, нәшер итү һәм тарату б-н шөгыльләнә. 1905 нең декабрендә кулга алына. 1906 да Оренбург шәһәренә сөргенгә җибәрелә, анда «Степь», «Оренбургский край» с.-д. г-талары б-н хезмәттәшлек итә. 1907 нең гыйнвар-апрель айларында Х.Ямашев һәм С. җитәкчелегендә с.-д.ның татарча «Урал» г-тасы нәшер ителә, ул ябылганнан соң С. Вятка губернасының Уржум шәһәренә җибәрелә. Сөргеннән кача, Уфа, Чиләбе һ.б. шәһәрләрдә революцион эшчәнлек алып бара. 1908–09 да кабат Уржумда сөргендә була. 1909 ның маеннан Казанда революцион эшчәнлеген дәвам итә, «Правда» г-тасы агенты була (1912–14). Казанда «Копейка рубль бережёт» кооператив җәмгыятен оештыручы һәм идарә әгъзасы. Җәмгыять аша Казан эшчеләре арасында революцион пропаганда алып барыла (1916). *Казан мөселман социалистлар комитетын* оештыруда катнаша (апр., 1917), аның президиумы әгъзасы, с.-д. секциясе җитәкчесе. «Аваз», «Кызыл Байрак» г-талары мөхәрририяте әгъзасы. 1917 нең октябрендә Казанда Совет хакимиятен урнаштыруда катнаша. Соңыннан Казанда кооперативлар оештыру эшен җитәкли. Чех-словаклар тарафыннан атып үтерелә.

*Әд.:* Г а р а ф у т д и н о в Р.А. Галимджан Сайфутдинов: Очерк жизни и деятельности. К., 1988.

*Р.А.Гарәфетдинов.*

**СӘЙФЕТДИ́НОВ** Рәфыйк Галимҗан улы (25.11.1951, Казан), кардиолог, мед. фән. д-ры (1991), проф. (1993). Иркутск мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1975), Иркутск клиник хастаханәсендә эшли. 1977 елдан СССР МФАнең Себер бүлеге Экспериментал клиник мед. ин-тында (Новосибирск ш). 1979 дан Иркутск мед. ин-тында, 1995–99 да эчке авырулар каф. мөдире, проф. патология курсын алып баручы. 1999 дан Казан мед. академиясенең терапия каф. мөдире, бер үк вакытта, 1993 тән, РМФАнең Себер бүлеге Көнчыгыш Себер ф-лы Хирургия фәнни-тикшеренү ин-тында фәнни-диагностика бүлеге мөдире. Хезмәтләре кардиология, гастроэнтерология, гематология, биофизика, биохимиягә карый. Уйлап табуга 10 патенты бар.

Х е з м.: Неотложные состояния в практике врача-терапевта: В 3 ч. Иркутск, 1989; Классификация наиболее распространённых болезней внутренних органов. Иркутск, 1991; Метод ЭПР в клинике внутренних заболеваний. Иркутск, 1993.

**СӘЙФЕТДИ́НОВ** Таһир Әгъзәй улы (2.3.1950, Тымытык р-ны Югары Эстәрле а. — 13.5.2008, Брянск ш.), генерал-лейтенант (1995). СССР Һава һөҗүменә каршы оборона гаскәрләре очучыларының Армавир югары хәрби авиация уч-щесен (1971), Сов. Союзы Маршалы Г.К.Жуков исем. Һава һөҗүменә каршы оборона хәрби командирлары академиясен (Калинин ш., 1984), СССР Кораллы Көчләре Генштабының К.Е.Ворошилов исем. Хәрби академиясен (Мәскәү, 1992) тәмамлый. 1982–90 елларда Мәскәү Хәрби округында СССР Һава һөҗүменә каршы оборона гаскәрләрендә: 1982–87 дә авиация часте командиры урынбасары, командиры, 1987–90 да берләшмә командиры урынбасары, командиры. 1990–92 дә СССР Һава һөҗүменә каршы оборона Сахалин дивизиясе башлыгы. 1992–98 дә Һава һөҗүменә каршы оборона 7 нче авиация кор-



Т.Ә. Сәйфетдинов.

пусы командиры (Брянск ш.). 1998–99 да РФ Саклык банкының Брянск бүлеге рәисе ярдәмчесе. 1999–2002 дә Брянскида «Бердәмлек» партиясе төбәк бүлеге җитәкчесе. 2005–08 дә Брянск өлкәсе хакимиятендә: идарә башлыгы, Төбәк иминлеге идарәсе башлыгы урынбасары. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СӘЙФИ́** Абруй Сәлах кызы (1890, Казан губ., Чистай өязе Күлбай-Мораса а. — 5.2.1960, Казан), журналист, педагог, җәмәгать эшлеклесе, тәрҗемәче. Язучы Ф.*Сәйфи-Казанлының* хатыны. 1905 елдан туган авылында мәктәптә укытучы булып эшли, 1908 дән — Чистай өязе Әдәмсу авылында, 1910 нан — Әстерхан шәһәрендә («Нәмүнәи тәрәккый»), 1914 тән — Рязань губ. Әзи авылында, Уфа шәһәрендәге Татар шәһәр уч-щесендә укыта. 1910 нан «Аң», «Идел», «Кояш», «Вакыт», «Эшче», «Татарстан» һ.б. газета һәм журналларда җәмгыятьтә татар хатын-кызларының хәле, балалар учреждениеләрен оештыру һәм эшләтү, үсеп килүче буынны тәрбияләү турындагы язмалары б-н катнаша. «Татарстан» г-тасында хатын-кыз тормышы бүлеге урынбасары. А.П.Чехов һәм А.Барбюс хикәяләрен татар теленә тәрҗемә итә. 1917 дән Мөселман соц. ком-тында, «Солдат хатыннары берлеге» («Союз солдаток») каршындагы мөселман солдат хатыннары бюросы рәисе, Болак арты-Пләтән һәм Берләшкән бистә р-ннары татар хатын-кызларын оештыручы, респ-ка татар хатын-кызлары арасында эшләү комиссиясе әгъзасы, ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тында хатын-кызлар бүлеге инструкторы (Казан). 1915 тә Уфа шәһәрендә концертларда вокаль номерлар б-н чыгыш ясый, соңрак Г.Кариев җитәкчелегендәге «*Сәйяр*» татар театры труппасы спектакльләрендә катнаша. «*Азат хатын*» ж-лын оештыручыларның берсе һәм аның хезмәткәре. 1937 елда халык дошманы хатыны буларак кулга алына; 1956 да аклана.

Х е з м.: Хатын-кызлар хәрәкәте һәм авылда эшләү. К., 1925; Татар хатын-кызлары азатлык юлында. К., 1927; Социализм төзегәндә хатын-кызлар һәм 8 март. К., 1930.

*Әд.:* Б у р н а ш е в а З., Г а у р о в а Г. Абруй Сәйфи // Азат хатын. 1960. № 9; Г и н и а т у л л и н а Р. Сайфи Абруй // Борцы за счастье народное. К., 1967.

**СӘЙФИ́** Тәлгать Фатыйх улы (19.5.1916, Вятка губ. Малмыж ш. — 8.7.1969, Түбән Новгород ш.), инженер-механик, пр-тие җитәкчесе, техник фән. канд. (1967). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1939), Саратов авиация з-дында эшли. 1948–56 елларда Арсеньев (Приморье крае), Комсомольск-Амур авиация з-длары баш инженеры. 1956–69 да Горький авиация з-ды баш инженеры, бер үк вакытта, 1967–69 да, Горький политехник ин-ты доценты. Самолёт конструкцияләре һәм аларны җитештерү технологияләре буенча хезмәтләр (50 гә якын) авторы. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медаль б-н бүләкләнә. «Сокол» з-дында (Түбән Новгород) иң яхшы технол. эшләнмәләр өчен С. исем. бүләк булдырыла. Казан техник ун-тында һәм Горький авиация з-дының Дан музеенда С. эшчәнлегенә багышланган стендлар бар.

**СӘЙФИ́** Хафиз Хәнәфи улы (1898, Саратов губ. — 1942), сәясәт эшлеклесе. 1914 елга кадәр Буа шәһәрендә (Сембер губ.), аннан соң Казанда яши һәм укый. Беренче бөтендөнья сугышы башланганнан соң, Бакуга китә. 1916 да революцион эшчәнлеге өчен кулга алына. 1917–18 дә Бакуда татар эшчеләре арасында сәяси һәм мәдәни-агарту эше алып барган «Берлек» с.-д. оешмасы секретаре. 1918 нең августында Әстерхан шәһәрендә яши. Әстерхан мөселман комис-ты һәм РКП(б) Әстерхан губерна ком-тының мөселман секциясе әгъзасы, «Көч», «Кызыл сөңге» г-талары мөхәррире. 1922–25 тә Казанда сәяси агарту системасында эшли. Аннан соң Урта Азия Хәрби Округында (Ташкент) хезмәт итә. 1929 дан Мәскәүдә — Кызыл Армиянең Баш сәяси идарәсендә. Репрессияләр чоры корбаны.

*Р.Г.Хәйретдинов.*

**СӘЙФИ-КАЗАНЛЫ́** (тәхәллүсе, чын фамилиясе Сәйфуллин) Фатих (Мөхәммәтфатих) Камалетдин улы (22.3.1888, Казан губ., Спас өязе Карамалы а. — 3.3.1937, Казан), язучы, җәмәгать эшлеклесе. «Мөхәммәдия» (Казан) мәдрәсәсендә укый. 1912–18 елларда Уфада яши, «Галия» (1915–17) мәдрәсәсендә укыта. 1906–17 дә «Йолдыз», «Тормыш» г-таларында, «Аң», «Ялт-Йолт», «Ак юл» ж-лларында әдәби-тәнкыйди һәм публицистик мәкаләләр бастыра. 1918 дән Казанда. Техникумнарда, 6 нчы берләштерелгән татар-башкорт (хәрби) командирлары мәктәбендә укыта, ТАССРның Мәгариф, Җир эшләре халык комис-тларында эшли. 1923–25 тә «Кызыл Татарстан», «Крестьян газеты» г-таларында, 1927–29 да «Яңалиф» ж-лында мөхәррир. 1926 ның апрелендә «*Яңалиф*» җәмгыяте б-н җитәкчелек итә башлый. 1930–35 тә Татар коммунистлар ун-тында, Татар пед. ин-тында укыта. Тарихи һәм сәяси мәсьәләләргә, Г.Кариев, Ш.Бабич, М.Гафури, Ш.Усманов һ.б. иҗатларына, татар әдәбияты үсешенә багышланган публицистик брошюралар һәм мәкаләләр авторы. 1913 тә «Аң» ж-лында басылган «Сәгыйть Сүнчәләй шигырьләре» мәкаләсендә нәфислек, субъектив башлангычның беренчеллеге, хисчәнлек, яңгыраш матурлыгы, гармония кебек аһәңлелек билгеләрен формалаштыра. «Футуризм» мәкаләсендә («Йолдыз» г-тасы, 1914) рус әдәбиятында авангард идеяләренә карата тискәре мөнәсәбәт белдерә, аларны «кысыр» һәм «үле туган» агымнар дип атый; татар әдәбиятында яңа үсеш юлларын эзләү психологизмны эмоциональ баету һәм тирәнәйтү, әдәби ысулларның төрлелеген арттыру хисабына барырга тиеш, ди. «Зимагур» (1921), «Крушниклар» (1921), «Двор өендә» (1925) хикәяләрендә революциягә кадәрге тормышны тәнкыйтьли; «Һани» (1923), «Елан токымы» (1931), «Кызыл эшелон» (1932), «Корбый иптәш» (1933), «Беренче адымнар» (1933) хикәяләр һәм повестьлар җыентыкларында, «Өч нарат» (1930) романында Гражданнар сугышы, социалистик төзелеш, күмәкләштерү вакыйгаларын тасвирлый. «Ямьсез тормыш» (1915, «Сәйяр» труппасы куя), «Җәмәгать хәдиме» (1916) пьесаларында татар җәмгыяте өчен мөһим булган хатын-кыз эмансипациясе һәм белем алу мәсьәләсен күтәрә, татар кызлары өчен гимназияләр булдыру идеясен яклап чыга. «Безнең заман» (1912; «Сәйяр» труппасы куя), «Дошманнар» (1921; Беренче татар дәүләт театры куя), «Зәкуан мулла шәҗәрәсе» (1929; Татар акад. театры куя), «Зәбәрҗәт» (1936; шунда ук куела) пьесаларында сыйнфый көрәш, яңа тормыш төзү күренешләре сәнгатьчә оста тасвирлана. Халыкның хокуксызлыгын, крәстиян общинасының таркалуын, авыл кешесенең авылдан читкә эш эзләп китүен сурәтләп, С.-К. тормышка буржуаз мөнәсәбәтләрнең үтеп керүен күрсәтә. Аерым хикәя һәм пьесаларында марксистик-ленинчыл идеяләрне пропагандалау өстенлек итә, геройларның үз-үзләрен тотулары психол. яктан ышандырырлык түгел. Г.Тукай (1–3 т., 1929–31), Г.Камал (1–2 т., 1929–30) әсәрләрен бастыру өчен текстологик әзерләү эшен башкара. С.Сүнчәләй, Г.Камал, Ф.Әмирхан иҗатларын өйрәнә («Өч татар классигы», 1929). Россия, Татарстан тарихына, француз рев-циясенә багышланган хезмәтләр, урта мәктәпләр өчен тарих дәреслекләре, атеистик характердагы мәкаләләр авторы. 1936 ның сентябрендә, *«Троцкийчы милләтчеләрнең контрреволюцион-террористик оешмасы» эше* буенча гаепләнеп, атып үтерелә; үлгәннән соң аклана.




Ф.К. Сәйфи-Казанлы.

Х е з м.: Татар иле. К., 1920 (автордаш); Сайланма әсәрләр. К., 1960.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1989. Т. 4; З а һ и д у л л и н а Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман. К., 2000.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**СӘЙФУ́ЛЛИН** Габбас Шиһабетдин улы (16.7.1887, Казан — 28.8.1951, шунда ук), педагог. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый (Казан). 1917 елга кадәр Казанның яңа алымлы (җәдит) мәдрәсәләрендә татар һәм рус телләрен укыта. 1919–27 дә Казанда татар үрнәк тәҗрибә мәктәбендә директор, 1927–29 да Шәрекъ пед. ин-тында укый. 1930–35 тә Казан ун-ты һәм Казан пед. ин-тының татар теле кафедраларында эшли, 1935–45 тә Казан фельдшер-акушерлык мәктәбендә һәм Казан пед. уч-щесендә татар һәм рус телләре укыта. 1932 дә, советка каршы эшчәнлектә гаепләнеп, кулга алына, 1933 тә аклана. Татар телендә гарәп, фарсы һәм европа телләреннән алынмалар сүзлекләрен бастыра: «Кечек лөгать» (1912), «Мәктәп лөга-



Г.Х. Сәйфуллин.

те» (1917); татар башлангыч мәктәпләрендә уку өчен рус әкиятләрен һәм Х.К.Андерсенның «Гадкий утёнок» әкиятен тәрҗемә итә. И.С.*Михеев* системасы буенча «Рәсемнәр буенча инша» («Сочинения по картинкам») ярдәмлеген татар телендә бастыра. 1920 еллар ахыры — 1930 еллар башында шәһәр һәм авыл мәктәпләре, рус мәктәпләрендә укучы татар балалары һәм өлкәннәр өчен яңалифтә берничә әлифба төзи: «Ярыш» («Соревнование»), «Яшь ударник» («Молодой ударник»), «Яңа ил» («Новая страна»), «Ленин юлы» («Ленинский путь»). 1946–59 елларда С.ның гомуми белем бирү мәктәпләре өчен кириллицадагы әлифбалары 13 тапкыр басыла. С. ш.у. әлифба укыту өчен укытучыларга ярдәмлекләр, татар башлангыч мәктәпләре өчен рус теле буенча уку ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Татарча рәсемле инша дәресләре: 2 бүлектә. К., 1914.

*Әд.:* Н у р м ө х ә м м ә т о в а Р. «Мәктәп лөгате» сүзлеге // Мәгариф. 2000. № 11.

**СӘЙФУ́ЛЛИН** Ганс Хәмит улы (26.02.1941, ТАССРның Баулы эшчеләр пос.), баянчы, композитор, ТРның халык артисты (2004). Баулы музыка мәктәбен тәмамлый (1958). 1961–87 елларда Г.Тукай исем. Татар филармониясендә баянчы булып эшли. 1976 да Ленинградта Т.Якупов б-н берлектә беренче пластинкасын яздыра. Ф.*Кудашева*, З.*Басыйрова*, И.*Шакиров* һ.б. күренекле җырчылар б-н эшли. Россия һәм чит илләрдә (Монголия, Тунис, Италия, Мальта, Төркия, Венгрия, Румыния, Австрия, Бельгия, Болгария һ.б.) актив концерт эшчәнлеге алып бара. С. иҗаты, композитор буларак, беренче чиратта, җыр жанры (якынча 400 җыр һәм инструменталь пьесалар) б-н бәйле. Аның «Туган авылым урамы», «Акбүз атым», «Җәйге урман» (Г.Зәйнашева сүзләре), «Миләүшә» (М.Галиев сүзләре), «Син илдә бер генә» (Р.Әхмәтҗанов сүзләре), «Карап калам кошлар артыннан», «Күрәсем килгән иде» (Ш.Җиһангирова сүзләре), «Бәхет дагасы» (И.Хөснетдинов сүзләре) җырлары зур популярлык казана.

Ә с ә р.: Ак Барс: Җырлар җыентыгы. К., 1995; Истәлеккә бер җыр бүләк итәм: Җырлар җыентыгы. К., 1996; Истәлеккә җырлар бүләк итәм. К., 2001.

*Әд.:* С а т и е в К. Татар баянчылары. К., 1996.

**СӘЙФУ́ЛЛИН** Гыйлаҗетдин Гайнетдин улы (1873, июль, Казан губ., Казан өязе Кече Рәс а. — 6.7.1946, Казан), музыка остасы, халык җырларын туплаучы. 20 йөз башында Казанда сәүдәгәр Г.Минкин кибетендә приказчик булып эшли, музыка уен кораллары ясый һәм төзәтә, 1900 еллар тирәсендә шәхси остаханәсен ача, «Стелла» һәм «Мир» муз. тартмачыклар өчен татар көйләре б-н пластинкалар әзерли. С. фонограф һәм грампластинкаларга Г.*Әлмөхәммәдов*, К.*Мотыйгый* һ.б. башкаруында татар җырларын яздыра. 1914–17 дә 400 дән артык халык көйләрен фортепиано өчен нотага күчерә һәм бастырып чыгара (Россия китапханәләрендә 4 басма хезмәте саклана). Үзлектән мандолинада уйнарга өйрәнү хезмәте авторы (1914).

**СӘЙФУ́ЛЛИН** Инсаф Шәрифулла улы (16.11.1945, Азнакай р-ны Күктәкә а.), химик-технолог, химия фән. д-ры (1994), проф. (1996), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1997), РФнең атказ. машина төзүчесе (2005). 1970 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1992–96 да һәм 2001 дән «АлАЗ» ЖБдә, техник җитәкче, ген. директор урынбасары, Фәнни-техник үзәк директоры. 1996–2000 дә РФ Федераль Җыенының Дәүләт Думасында: Конверсияләр һәм фәнни технологияләр ком-ты рәисе урынбасары, «Наш дом — Россия» фракциясе җитәкчесе урынбасары, Тотрыклы үсеш проблемаларын законнар б-н тәэмин итү комиссиясе рәисе. 2001–02 дә РФнең Сәнәгать, фән һәм технологияләр министрлыгында. 2002 дән «Газпром» АҖдә, бүлек башлыгы, Газны транспортлау, җир астында саклау һәм файдалану департаментының энергия саклау һәм экология идарәсе башлыгы урынбасары. Хезмәтләре термик таркалу реакцияләренә карый. С. гетероароматик C-нитрокушылмалар, фуразаннар, фуроксаннар, N-оксидларның мономолекуляр термик таркалу реакцияләренең башлангыч стадияләре механизмын ачыклый, кинетик параметрларын билгели; бу кушылмаларның химик төзелеше б-н реакциягә сәләте арасындагы бәйләнешне ачыклый. Зур энергияле органик кушылмаларның структур формуласы буенча эксплуатация характеристикаларын фаразлый һәм бирелгән үзлекле яңа энергетик материаллар эшләргә мөмкинлек бирә торган исәпләү алымын тәкъдим итә. Оригиналь конструкцияле һәм югары нәтиҗәле экологик эчке янулы двигатель, табигый газны сыек углеводородларга әверелдерүче җайланма уйлап табуда катнаша. 1995–2000 дә Дәүләт Думасы депутаты. «Оборона сәнәгате конверсиясе турында», «Өстенлекле фәнни технологияләр турында» һ.б. федераль законнар проектларын әзерләүдә; РФнең экологиягә һәм энергия саклауга караган программаларын кабул итүдә катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Прогнозирование скоростей реакции гомолитического термораспада органических соединений с использованием принципа наименьшего движения // Кинетика и катализ. 1993. № 6 (автордаш); Энергия диссоциации связей N-O производных пиридиноксида // Изв. РАН. Сер. хим. 1995. № 4 (автордаш); Задача информационно-метрологического обеспечения научных исследований и создания передовых технологий // Новые высокие технологии для газовой, нефтяной промышленности, энергетики и связи. М., 2006. Т. 16 (автордаш).

**СӘЙФУ́ЛЛИН** Искәндәр Фоат улы (25.7.1955, Казан), архитектор, педагог, үзешчән музыкант. 1978 елда Мәскәү архит-ра ин-тын тәмамлаганнан соң (проф. Е.С.Русанова остаханәсе), Казан архит-ра-төзелеш ун-тының архитектур проектлау кафедрасында эшли, Акад. социо-фәзаи эзләнүләр лаб-ясе җитәкчесе (ALSER KSABU). Бер үк вакытта, 2006 дан, «4D-Atelier» ҖЧҖ баш архитекторы. ТР Архитекторлар берлеге рәисе (2004–05). 1997–2001 дә, әйдәп баручы автор буларак, Кол Шәриф мәчетен проектлауда катнаша (С.П.Шәкүров б-н берлектә). ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2012).

**СӘЙФУ́ЛЛИН** Мөхәммәтгали Сәйфулла улы (1794, Казан губ., Малмыж өязе Түнтәр а. — 5.8.1874, шунда ук). Түнтәр, Сасна, Мәчкәрә мәдрәсәләрендә Мөхәмметкәрим әл-Ашыти, Габдулла бине Яхъя, Таҗетдин әл-Иштирәк һәм башка танылган мөгаллимнәрдән белем ала. 1814–24 елларда Бохарада күренекле шәрекъ галимнәрендә укый. Коръәнне тирәнтен үзләштерә. Гатаулла әл-Бохари карашлары йогынтысында суфичылык дини-фәлсәфи тәгълиматын өйрәнә. Шуның б-н Бохара ханының игътибарын җәлеп итә, аның ышанычын казана һәм йомышчысы-илчесе сыйфатында Кытайга җибәрелә, Кабул, Лахор, Кандаһар, Пәшәвәр, Дәһли кебек мөселман үзәкләренә сәяхәт кыла. 1829 да, туган авылы Түнтәргә кайтып, мәдрәсә ача һәм балалар укытырга керешә. 1834 тә мәчет төзетә һәм аның имам-хатыйбы булып эшли. Күпкырлы тирән белемле, күркәм шәхси сыйфатларга ия булуы, өстәвенә дәвалау серләрен белүе аны тирә-якта үз заманының абруйлы дин эшлеклесе итеп таныта. Суфичылык мөршиде буларак, аның мөридләре Россиянең төрле төбәкләренә тарала. Аның йогынтысында тирә-як авыллардагы марилар, удмуртлар арасында ислам динен кабул итүчеләр була. Моның өчен халык алдында чыбык б-н суктырыла. Гали ишан — ике тапкыр Нәкышбәндийә борадәрлеге ордены б-н бүләкләнгән сирәк затларның берсе. Ш.Мәрҗани Гали ишанның хезмәтләренә югары бәя бирә. «Мәмләкәтебездә булган ишаннарның бөтенесеннән белемлерәге, танылганрагы, дөресрәге иде», — дип яза.

**СӘЙФУ́ЛЛИН** Равил Зиннәт улы (14.7.1936, Казан), икътисад фән. д-ры (1986). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1959), «Красный строитель» з-дында (Фрунзе ш.) план бүлеге икътисадчысы, цех башлыгы булып эшли. 1964 елдан Кыргызстан ССР ФАнең Икътисад ин-тында, 1976–83 тә Кыргызстан ССР Госпланының Икътисад һәм планлаштыруның икътисади-математик ысуллары фәнни-тикшеренү ин-тында җитештерүче көчләрне үстерү һәм урнаштыру бүлеге мөдире. 1983 тән РСФСР Госпланы Үзәк икътисад фәнни-тикшеренү ин-тының Төньяк-көнбатыш ф-лында хезмәт ресурслары һәм халыкның тормыш дәрәҗәсе секторы мөдире. 1992 дән РФ Дәүләт милке б-н идарә ком-тының Хосусыйлаштыру проблемалары дәүләт ин-тында (С.-Петербург) әйдәп баручы хезмәткәр, 1994–97дән С.-Петер-

бург мэриясенең Матбугат һәм гаммәви мәгълүмат чаралары б-н бәйләнешләре ком-тының икътисад бүлеге белгече. Фәнни тикшеренүләре җитештерүче көчләрне үстерү һәм урнаштыру, дәүләтнең базар икътисады б-н идарә итүе һәм аны көйләве, иҗтимагый җитештерүнең нәтиҗәлелеге теориясен эшләүгә карый. Ленинград «Ватан» татар җәмгыяте президенты (1990 нан).

Х е з м.: Темпы, пропорции и эффективность общественного производства в Киргизской ССР. Фр., 1976. *Ф.С.Зыятдинов.*

**СӘЙФУ́ЛЛИН** Рәшит Фәйзрахман улы (1919, Уфа губ. — 9.10.1953, Мәскәү), график. 1930–33 елларда Уфа сәнгать уч-щесендә укый. 1937–40 та Мәскәү метрополитенында эшли. 1935 тән С. рәсемнәре «Ударник Метростроя»да, һ.б. Мәскәү г-таларында басыла. Карикатуралары ТАСС оештырган рәссам-карикатурачылар күргәзмәсендә 1 нче урынны ала (1938). 1938 дән Д.С.Моор сәнгать студиясендә укый. 1941 дә армиягә алына; фронтта контузияләнә, вакытлыча демобилизацияләнә; шул ук елда Казанга килә, Татар дәүләт нәшриятында агитация плакатлары чыгаруда актив катнаша; 1943–45 тә яңадан Кызыл Армиядә. 1945 тән Мәскәүдә яши, «Детгиз» нәшрияты б-н хезмәттәшлек итә. С.ның рәссам буларак таланты һәм табигый сәләте сатира (агитация плакаты) һәм китап графикасында ачык чагыла. Аның плакатлары зур тиражлар б-н басыла (30 мең данәгә кадәр), югары проф. дәрәҗәдә булулары, фикер оригинальлеге, образларның хәтердә калырлык ачыклыгы, персонажлар һәм вакыйгаларның характер кискенлеге һәм төгәллеге б-н аерылып торалар. С. Германия фашизмын ачы көлеп фаш итә (мәс., национал-фашизмны явыз, йоны йолкынган Саламторхан рәвешендә сурәтләгән «Саламторхан» картинасы, 1941); совет кешеләренең тылдагы хезмәт батырлыгы темасын күтәрә, татар хатын-кызларының героик образын иҗат итә: «Кызыл Армиягә — җылы киемнәр», «Яңа тәртип» (икесе дә — 1941), «Фашистларны тар-мар итик!», «Һәрбер орлык — дошманга удар ул!», «Капитализмның бәйдәге этләре», «Кырларда совет сугышчылары




Р.Ф.С ә й ф у л л и н. «Һәрбер орлык – дошманга удар ул!» плакаты. 1942. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

фашист ерткычлары б-н көрәшкән кебек эшлик» (барысы да — 1942). Плакатларының сәнгать теленә матур силуэт, төсле локаль тапларның (кара, сары һәм кызыл) контрастлылыгы хас. Сугыштан соң ул китаплар иллюстрацияләүче һәм бизәүче булып эшли. «Габдулла Тукай. Шигырьләр» («Габдулла Тукай. Стихотворения», М.–Л., 1948) китабындагы «Кәҗә белән сарык» әкиятенә, М.Аүэзовның «Абай» романына (М., 1948) рәсемнәр, «Детгиз» нәшрияты чыгарган



Р.Ф.С ә й ф у л л и н.
«Габдулла Тукай. Шигырьләр » китабындагы «Кәҗә белән сарык» әкиятенә иллюстрация.


«Пушкин әкиятләре»нә («Пушкинские сказки»), «Башкорт халык әкиятләре»нә («Башкирские народные сказки»), «Канатлы ат» («Конёк-Горбунок») әкиятенә (1950–52) иллюстрацияләр иҗат итә.

С.ның әсәрләре А.С.Пушкин Музей-йортында (Мәскәү), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.

*Әд.:* Е л ь к о в и ч Л.Я. Сатирическая графика Татарии. М., 1963; Ф а й н б е р г А.Б. Политический плакат Казанских художников. 1941–45. К., 1965; Ч е р в о н н а я С.М. Искусство Советской Татарии. М., 1978.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**СӘЙФУ́ЛЛИН** Ренат Сәлах улы (5.7.1930, Казан), электрохимик, техник фән. д-ры (1970), ТР ФА академигы (1992), ТАССРның, РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1984, 1990), Казан технол. ун-тының атказ. профессоры (2005). 1953 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, нәорганик матдәләр каф. профессоры (1971), мөдире (1973–2000). Хезмәтләре гамәли нәорганик химиягә, электрохимиягә, гальваностегиягә карый. С. — *композицион электрохимик капламнар* (КЭК) һәм материаллар ясау буенча фәнни юнәлешкә нигез салучы. Ул яңа төр гальваник капламнар; никель һәм палладий капламнарның калынлыгын тикшерүнең әлеге дефицит металлар чыгымын киметә торган ысулларын эшли (илнең машиналар һәм приборлар төзү пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән). Дисперс фаза өстәлмәсе (химик һәм физик табигате төрле булган микро- һәм субмикроүлчәмдәге кисәкчәләр рәвешендәге химик яктан тотрыклы кушылмалар: графит, алмаз, кремний, боридлар, оксидлар, карбидлар, нитридлар, органик полимерлар һ.б.) ярдәмендә суспензиягә яки гельгә әвереларелгән электролитлардан аерып алына торган КЭК технологиясенең фәнни нигезләрен эшли. Аларны



Ренат С. Сәйфуллин.

киң кулланылыштагы һәм төрле формадагы эшләнмәләр җитештерүдә калынлыгы теләсә нинди һәм алдан бирелгән физик һ.б. үзлекләргә ия булган катламнар рәвешендә файдалану мөмкинлеге туа. С.ның фәнни хезмәтләре җитештерүгә кертелгән, алар машиналар һәм приборлар төзү, электротехника, электроника һәм сәнәгатьнең башка тармакларында эшләнмәләрнең өслекләрен камилләштерүдә кулланыла. Тикшеренүләре нәтиҗәсендә 6 монография нәшер ителә. Фәнни хезмәтләре комплексы һәм күп кенә процессларны сәнгатьтә уңышлы гамәлгә ашырганы өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (1994). Табигыять белемен һәм химия-физика фәннәренең яңа казанышларын актив пропагандалый. Д.И.*Менделеевның* элементларның хәзерге заман периодик системасының русча вариантын эшли һәм нәшер итә. Нәорганик материаллар, капламнар һәм матдәләр, коррозиядән саклау; кристаллохимия һәм минералогия, җитештерү җиһазлары һ.б. фәнни өлкәләргә караган 16 монография һәм уку ярдәмлеге авторы.

Уйлап табуга 50 дән артык авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. Д.И.Менделеев исем. Бөтенсоюз химия җәмгыяте бүләге лауреаты (1973). «Почёт билгесе», Дуслык орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Комбинированные электрохимические покрытия и материалы. М., 1972; Универсальный лексикон: химия, физика, технология (на русском и английском языках): Справ. М., 2001 (автордаш); Современная химико-физическая энциклопедия — лексикон (на русском и английском языках). К., 2010 (автордаш); Достижения естественных наук и эра Нобелевских премий = Progress of Natural Sciences and Era of Nobel Prizes. К., 2005 (автордаш); Physical Chemistry of Inorganic Polymeric and Composite Materials. L., 1992.

*Әд.:* Профессор, академик АН Татарстана Ренат Саляхович Сайфуллин: Очерки жизни — прошлое и настоящее. Факты, документы, труды: Биобиблиогр. К., 1997; Лидеры научных школ КХТИ — КГТУ. К., 2007.

**СӘЙФУ́ЛЛИН** Рөстәм Сөләйман улы (30.6.1930, Ташкент), геофизик, геол.-минерал. фән. д-ры (1975), проф. (1993). Львов политехник ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), шунда ук эшли. 1957–77 елларда Чита шәһәрендә: 1957 дән Геол. идарәсендә, 1959 дан Байкал аръягы комплекслы фәнни-тикшеренү ин-тында, директор урынбасары (1970 тән). 1977–99 да Украина геол. разведка ин-тында (Львов ш.), баш фәнни хезмәткәр (1987 дән). Хезмәтләре руда һәм нефть геофизикасына карый. Руда барлыкка килүдә электрохимик процесс турында фаразны әйтә, разведкалауның электрохимик алымнарын үстерә, углеводород ятмаларының геоэлектрик модельләрен һәм электроразведкалау мәгълүматларын эшкәртү алгоритмнарын һәм интеграль программалаш-

тыру ысулларын эшли. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Эффективность поиска и разведки рудных месторождений. Львов, 1982; Основы сейсморазведки. М., 1995 (автордаш); Ещё раз о геоэлектрических факторах формирования нефтегазоносных недр // Геол. журн. 2007. № 2.

**СӘЙФУ́ЛЛИН** Сәет Шаһимәрдән улы (3.10.1905, Акмола губ. Атбасар ш. — 22.5.1985, Алма-Ата), геолог, Казакъстан ССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1970), Казакъстан ССРның атказ. геологы (1965). Мәскәү геол.-разведка ин-тын тәмамлаганнан соң (1932), Җизказган руднигында (Казакъстан ССР) эшли. 1956–64 елларда Мәскәүдә: СССР төсле металлургия министрлыгында, 1957 дән СССР Госпланында. 1964 тән Казакъстан ССР ФА Геол. фәннәре ин-тының комплекслы тикшеренүләр лаб-ясе мөдире (1978 дән консультант). Хезмәтләре руда чыганаклары геологиясенә карый. С. — Казакъстан терр-ясендә бакыр, марганец һәм рений чыганакларын ачуда катнашучыларның берсе. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, «Чыганакларны беренче ачучы» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Стратиформные месторождения меди Западной части Центрального Казахстана. А.-А., 1976 (автордаш).

*Әд.:* Казахская ССР: Краткая энцикл. А.-А., 1989. Т. 3.

**СӘЙФУ́ЛЛИН** Фуад Габбас улы (16.7.1921, Казан — гыйн., 2003, шунда ук), бит-казналык хирургы, стоматолог, мед. фән. д-ры (1970). Казан стоматология ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), ТР ФАнең Травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү үзәгендә (Казан). 1959–88 елларда Казан мед. ин-тының хирургик стоматология кафедрасында, бер үк вакытта, 1971–73 тә, стоматология ф-ты деканы. Хезмәтләре бит-казналык хирургиясенә: стоматологиядә дефектлар пластикасы вакытында «Филатов сабагы»н куллануга; яман шеш алды авыруларын дәвалауга карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче, 2 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы орденнары, Кызыл Йолдыз ордены, Монголия, Чехословакия орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Некоторые биологические особенности филатовского стебля и их значение при пластике дефектов челюстно-лицевой области. К., 1963.

**СӘЙФУ́ЛЛИНА** Гөлшат Ибраһим кызы (24.1.1927, Казан — 11.8.2010, шунда ук), җырчы (лирик-драматик сопрано), педагог, ТАССРның халык (1964), РСФСРның атказ. артисты (1978). 1950 елда Казан консерваториясен (К.Цветов классы) тәмамлый. 1950–79 да Татар опера һәм балет театры солисты, бер үк вакытта, 1975 тән, Казан консерваториясендә укыта (1987 дән проф.). Недда («Шамакайлар», Р.Леонкавалло), Чио-Чио-сан (шул исем. әсәр буенча, Дж. Пуччини), Маженка («Сатып җибәрелгән кәләш», Б.Сметана), Татьяна, Лиза («Евгений Онегин», «Пики дамасы», П.Чайковский), Микаэль («Кармен», Ж.Бизе), Купава («Кар кызы», Н.Римский-Корсаков), Катерина («Катерина Измайлова», Д.Шостакович), Настя («Тарас гаиләсе», Д.Кабалевский),



Г.И. Сәйфуллина.

Рәйхана, Аембикә («Качкын», «Түләк һәм Сусылу», Н.Җиһанов), Әлфия («Самат», Х.Вәлиуллин), Бибисара («Җиһангир», Р.Гобәйдуллин), Галия («Тапшырылмаган хатлар», Җ.Фәйзи) һ.б. партияләрне башкара. Концерт эшчәнлеге алып бара. С., камера җырчысы буларак, Ф.Шубертның «Кышкы юл» («Зимний путь») циклын аеруча уңышлы башкара. Көчле, тигез яңгырашлы тавышка ия, сәхнәдә төрле пландагы образлар тудыра; теге яки бу әсәрнең эчтәлегенә тирәнтен төшенеп, ихлас күңелдән тәэсирле башкаруы б-н аерылып



Г.И. С ә й ф у л л и н а Наталья ролендә («Тын Дон», И.И. Дзержинский).

тора. С.ның камера җыры классы буенча укучылары арасында В.Ганиева, Г.Ибушев, К.Хәйретдинова, М.Якупов, А.Фәйзрахманов, Р.Маликов һ.б. бар.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980.

**СӘЙФУ́ЛЛИНА** Лидия Николаевна (22.3.1889, Оренбург губ. Варламово пос. — 25.4.1954, Мәскәү), язучы. «Дүрт башлык» («Четыре главы»), «Нух көймәсе» («Ноев ковчег»), «Черемә» («Перегной»), «Хокук бозучылар» («Правонарушители») — барысы да — 1922, «Виринея» (1924), «Очрашу» («Встреча», 1925), «Хаин кабак» («Каин-кабак», 1926), «Үз җиреңдә» («На своей земле», 1946) повестьлары, «Юлдашлар» («Попутчики», 1924) романы, «Наташа» (1937), «Угыл» («Сын», 1949) пьесалары, хикәяләр, очерклар авторы. 1933 елда, 1 нче Бөтенсоюз язучылар съездына әзерлек б-н бәйле рәвештә, бер төркем Мәскәү язучылары б-н Казанга килә. Казан әдипләре һәм журналистлары б-н очраша; С.ның Заречье эшчеләр клубындагы чыгышы «Мин ничек язам» («Как я пишу») темасына багышланган. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Собр. соч.: В 6 т. М.–Л., 1929–31; Сочинения: В 2 т. М., 1980.

*Әд.:* Лидия Сейфуллина в воспоминаниях современников. М., 1961; Я н о в с к и й Н. Лидия Сейфуллина: Критико-биогр. очерк. М., 1972; Русские писатели. XX век: Биогр. словарь. М., 2000.

*Г.А.Балакин.*

**СӘЙФУ́ЛЛИНА** Фәридә Равил кызы (23.9.1959, Казан), офтальмолог, мед. фән. д-ры (2009). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1982), Казан ГИДУВында (бүлекнеп, 1985–88 елларда Мәскәүдә, Үзәк табибләр белемен күтәрү ин-тында), 1988 дән күз авырулары кафедрасында, 2010 нан проф. Шикәр диабеты, хроник В гепатиты, алкоголизм һ.б.лар б-н бәйле күз авыруларын тикшерә. Хезмәтләре эре сәнәгатьле шәһәрләрдә мәктәп балаларының күз авырулары үзенчәлекләренә, техноген пычрануларның глаукома авыруы таралуга тискәре йогынтысын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Изучение глазной патологии и её профилактика в условиях техногенного загрязнения окружающей среды в крупном промышленном городе: Учеб. пособие. К., 2008; Математическое моделирование в оценке неблагоприятного техногенного загрязнения городской среды на распространённость глаукомы // Материалы Междунар. науч.-практической конф. Новые технологии в офтальмологии. К., 2008.

**СӘЙФУ́ЛЛИНА** Флёра Сәгыйть кызы (22.1.1966, Буа р-ны Яңа Тинчәле а.), әдәбият белгече, филол. фән. д-ры (2008), проф. (2010), РФнең югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре (2007), ТРның атказ. укытучысы (2008). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1989). 1990 елдан Тубыл социаль-пед. академиясендә, 2011–16 да Казан ун-тында. 2016 дан ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф идарәсе башлыгы. Хезмәтләре татар әдәбияты тарихына, Себер татар әдәбияты үсеше һәм формалашу тарихына, С.Сөләйманова, Я.Зәнкиев, Б.Сөләйманов иҗатларына карый.

**СӘЙФУ́ЛЛИНА** Хәлимә Мөхлис кызы (26.12.1928, Казан — 10.1.2007, шунда ук), стоматолог, мед. фән. д-ры (1980), проф. (1980), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1980). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), Йошкар-Олада, Казанда (Юдино) эшли. 1959 елдан Казан мед. ин-тында, 1977 дән балалар стоматологиясе каф. мөдире, стоматология ф-ты деканы (1981–84). Респ-ка хатын-кызлар ком-ты рәисе урынбасары (1984–90). Хезмәтләре балалар һәм яшүсмерләрдә теш кариесын кисәтүгә, организмның резистентлыгын һәм аллергия реакцияләрен өйрәнүгә карый. Уйлап табуга патенты бар (стоматологиядә димефосфонны аерым урынны дәвалау өчен куллану). 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены, медаль; Монголиянең Бөек халык хуралы Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Кариес зубов у детей и подростков. К., 1984; Актуальные вопросы стоматологии детского возраста. К., 1990.

*Әд.:* Профессор Халима Мухлисовна Сайфуллина // Казан. мед. журн. 1998. № 6.

**СӘЙХУ́НОВ** Вәлиулла Гафият улы (2.7.1929, Буа кантоны Морзалар а. — 6.06.2012, Апас р-ны Морзалар а.), галим агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1983, 1989). Казан а.х.

ин-тын тәмамлый (1970). 1945–90 елларда Апас р-нында эшли: хисапчы, Дәүләки МТСнда тракторчы, К.Маркс исем. к-зда шофёр, тракторчылар бригадасы бригадиры, к-з рәисе (1959 дан), Свердлов исем. к-з рәисе (1961 дән), «Свердловский» с-зы директоры (1973). С. җитәкче булганда совхозда 510 баш мөгезле эре терлек өчен ферма, 100 мең тавык өчен кошчылык ф-касы, тегермән, механикалаштырылган вакытлыча ашлык саклау урыны (ындыр табагы), урта мәктәп, мәктәп-интернат, клуб һәм башка җитештерү объектлары, соц.-мәдәният һәм көнкүреш биналары төзелә. Ит җитештерү 69% ка, сөт — 31% ка, бөртекле ашлык 32% ка, еллык савым һәр сыердан уртача 39% ка арта. Җитештерүдәге югары күрсәткечләре өчен совхоз 1975 тә, 1977–78 дә КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКларының күчмә Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**СӘЙЯДИ́** (тулы исеме Кылыч бине Сәйяд) (15 йөз, башка мәгълүматлар буенча, 18 йөз), төрки шагыйрь. Бәлх яки Хәйдәрабад шәһәрендә (Әфганстан) яши. Әдәбият галиме Ф.Яхин фикеренчә, чыгышы б-н Сәйяд шәһәреннән (хәзер Үзбәкстанның Үргәнч ш. тирәсендә) булуы ихтимал, төрекмән галиме Ә.Күлмөхәммәдов фикеренчә, Сәйядләр төрекмән кабиләсе вәкиле булуы мөмкин. *«Дастаны Бабахан»* поэмасы авторы. Дастанның сюжетына Ә.Кормаши «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» поэмасын һәм Ф.Бурнаш «Таһир-Зөһрә» драмасын иҗат итәләр.

Ә с ә р.: Таһир-Зөһрә (Бабахан дастаны). К., 1998.

*Әд.:* И с л а м о в Р. Ещё об одном варианте дастана «Тахир и Зухра» // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2005. № 2; А х м е т з я н о в М.И. Татарские версии сюжета «Тахир-Зухра» // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). К., 2007; А х м е т о в а - У р м а н ч е Ф.В. «Дастан-и Бабахан» Сайяди // шунда ук.

**«СӘЙЯ́Р»** (гарәп. سيار — ил гизүче, мосафир), профессиональ татар театр труппасы. 1907 елның ноябрь–декабрендә И.Кудашев-Ашказарский труппасының (к. *Россиядә Беренче күчмә мөселман драма артистлары труппасы*) Мәскәүдәге гастрольләреннән соң таркалуы нәтиҗәсендә оеша. Г.Кариев җитәкчелегендәге бер төркем актёрлар — В.Мортазин-Иманский, Ә.Кулалаев, Н.Гайнуллин, Н.Хәйретдинов, С.Гыйззәтуллина-Волжская, Ф.Шаһимәрданов Уральск шәһәренә килә һәм анда «Мосафир артистлар җәмгыяте» исемле труппа оештыра. Аның составында ш.у. Н.Сакаев, Г.Болгарский да була; режиссёр эшенә рус театры актёры Н.Зимовой җәлеп ителә. Г.Камалның «Бәхетсез егет» пьесасы буенча спектакль әзерләгәннән соң, труппа Кырым, Кавказ, Россиянең Көньяк шәһәрләре буйлап гастрольләргә чыга (1908). Тифлис (хәзер Тбилиси) шәһәрендә Г.Кариев труппасы Г.Араблинский җитәкчелегендәге әзәрбайҗан труппасы б-н берләшә, һәм шул рәвешчә *Казан-Кавказ мөселман артистлары ширкәте* оеша. Уртак гастрольләрдән соң ширкәт таркала, Г.Кариев җитәкчелегендәге труппа «С.» дип атала



«Сәйяр» труппасы (сулдан уңга – утырганнар: Ф. Әхмәдова, Ф. Сәмитова, С. Гыйззәтуллина-Волжская, Г. Болгарский, В. Мортазин-Иманский; басканнар: Г. Кариев, Н.Сакаев). 1909.

башлый. 1911 дән Казандагы Шәрекъ клубы труппаның даими җирлегенә әйләнә. Төрле елларда труппа составында ш.у. З.Солтанов, К.Шамил, Н.Арапова, Ә.Синяева, Ф.Сәмитова, Г.Болгарская, Н.Таҗдарова, Б.Тарханов, М.Мутин, К.Тинчурин эшли. Г.Камал, Г.Исхакый, Г.Коләхмәтов, Ф.Әмирхан, С.Рәмиев, Я.Вәли, Ф.Бурнаш, Ф.Сәйфи-Казанлының күп кенә пьесаларын беренче тапкыр сәхнәләштереп, «С.» труппасы милли репертуар барлыкка килүгә булышлык итә. Татар драматурглары пьесалары б-н беррәттән төрек һәм әзәрбайҗан драматурглары пьесалары («Кызганыч бала», Н.Кәмал; «Надиршаһ», Н.Нариманов), ш.у. рус һәм дөнья классикасы әсәрләре («Өйләнү» («Женитьба»), «Ревизор», Н.В.Гоголь; А.Н.Островский пьесалары, А.П.Чехов водевильләре; «Мәкер вә мәхәббәт» («Коварство и любовь»), Ф.Шиллер; «Мещаннар» («Мещане»), М.Горький) буенча да спектакльләр куела. Рус театры тәҗрибәсен иҗади үзләштереп, «С.» труппасы татар милли реалистик театр традицияләрен һәм мәктәбен формалаштыра, халыкны агарту һәм тәрбияләү бурычларын хәл итә. 1918 дә, Гражданнар сугышы б-н бәйле рәвештә, труппа таркала, актёрлар татар фронт театр төркемнәренә таралыша. «С.» труппасының күп кенә актёрлары 1920 нең октябрендә ТАССР Мәгариф халык комис-ты коллегиясе карары нигезендә оешкан Беренче татар дәүләт драма труппасына (соңрак Татар акад. театры) урнаша.



1915 елны ЖОМГА КӨН 31 июль

ТАТАРЧА СПЕКТАКЛЬ

ТИГЕЗСЕЗЛӘР

II

ИРЕМ КАЙТТЫ

УЕН КИЧ

«Сәйяр» труппасы афишасы.

*Әд.:* М о р т а з и н В., Ч е н ә к ә й Т. Татар театры тарихыннан. М., 1926; Татар совет театры. К., 1975; Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; М ә х м ү т о в Һ. «Сәйяр» труппасы // Мирас. 1998. № 4–7, 9; И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала: Биогр. белешмәлек. К., 2005; С а р ы м с а к о в Ш. А.Кариев. К., 1957; И л я л о в а И. Театр имени Камала. К., 1986; А р с л а н о в М.Г. Татарское режиссёрское искусство 1906–1941. К., 1992.

*И.И.Илялова.*

**СӘКЕ́**, Казан татарларында торакның традицион интерьер предметы. Мишәрләрдә — урдык, Касыйм татарларында — ундык, Әстерхан татарларында — тохтамбит, Себер татарларында урынтык исемнәре б-н билгеле. Гадәттә, алгы дивардагы биек булмаган турыпочмаклы киң такта түшәмә (биеклеге 1 *м* га кадәр); йортның эчке күренешендәге күп функцияләрне үтәүче элемент. Татар йортларында җиһазлар барлыкка килгәнче, С. агымдагы хуҗалык һәм катлаулы булмаган һөнәрчелек эшләрен (бәйләү, чигү һ.б.) үтәү урыны булып хезмәт иткән, ш.у. ашау-эчү урыны да булып торган: кунаклар кабул итү өчен С. уртасына ашъяулык (Әстерхан татарларында — тастархан) җәелгән, аның тирәсендә сырган көрпәләрдә хуҗалар һәм кунаклар утырышкан. С.дә урын-җир урнаштырылган: киез яисә сугылган палас өстенә мамык түшәк, ястык-мендәрләр, юрганнар түшәлгән. С.дә торак күренешенең төрле предметлары: сандыклар, уку һәм язу өчен тәбәнәк өстәлләр, урын-җир әйберләре, бишек һ.б. урын ала. Татарларда ш.у. мич алдында, гадәттә, икмәк һәм кулинария әйберләре әзерләнә, савыт-сабалар юыла торган урында караватһәм өстәл формасындагы С.ләр дә кулланылган. 20 йөз урталарына, көнкүрешкә фабрика-заводларда җитештерелгән җиһазлар килеп кергәч, кулланылыштан чыга.

*Әд.:* Х а л и к о в Н.А. Сельские поселения и жилища // Татары. М., 2001; Этнография татарского народа. К., 2004.

**СӘКЕ́Л** елгасы, Идел алдында, Зөя елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 29,4 *км*, бассейнының мәйданы 138,1 *км*². Идел буе калкулыгы буйлап, Яшел Үзән р-нында ага. Елга башы Чуаш Респ-касында, Кызыл Таң посёлогыннан көнбатыштарак, Мизиново авылыннан 3 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Куйбышев сусаклагычының Зөя култыгына коя. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. С.нең 2,6 дан 8,3 *км* га кадәр озынлыктагы 9 кушылдыгы бар. Елга челтә-

ренең тыгызлыгы 0,46 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык ташу агымының уртача күпьеллык катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Җәен елга еш кына кибә һәм тамагына кадәр барып җитми. Суы ел дәвамында чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. С.нең югары агымында суының гомуми күләме 0,9 млн. *м³* булган буа бар.

**СӘКИНӘ́С** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 25 *км* көньяктарак, Пакшин елгасы буенда. 2010 елда 171 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1646 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Троицкий, Сикинези исемнәре б-н билгеле. Халкы башта ясаклы (1719–24 тә — дәүләт) крәстияннәр катлавына керә, 18 йөзнең 2 нче яртысында Кама казна тимер эшкәртү з-дына беркетелә; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, Троица чиркәве (1871 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1869 да ачыла), 1 су һәм 3 җил тегермәне, 1 зур, 1 казна шәраб һәм 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2254 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Троицк-Сәкинәс волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 266 ир-ат; 1859 да — 1157, 1897 дә — 1381, 1908 дә — 1424, 1920 дә — 1558, 1926 да — 1620, 1938 дә — 1098, 1949 да — 593, 1958 дә — 481, 1970 тә — 491, 1979 да — 345, 1989 да — 255, 2002 дә — 195 кеше.

**СӘКЪЛӘ́Б** (гарәп. صقالبة), 8–12 йөзләрдә гарәп язмаларында Европада яшәүче күп кенә халыклар атамасы. Иң беренче славяннарны шулай атыйлар. 9–10 йөзләрдә, гарәп авторлары фикеренчә, чыгышлары уртак, яшәү рәвеше, хуҗалык алып барулары охшаш булган европа халыкларына гомуми атама буларак кулланыла башлый. Кайбер авторлар, мәс., әл-Максуди аларга төрки халыкларны да кертә. Багдад хәлифәсе әл-Моктадир илчелеге сәркәтибе Ибне Фазлан үзенең язмаларында Идел буе Болгары идарәчесе (921–23) Алмыш илтәбәрне С.лар әмире дип атый, бу исем астында Урта Идел буе җирле төрки-угор халкын күз алдында тота. 12 йөздә «С.» термины әкренләп кулланыштан төшә һәм халыкларның үз-үзләренә биргән атамаларына алыштырыла.

*Әд.:* Б а р т о л ь д В.В. Славяне // Сочинения. М., 1963. Т. 2, ч. 1; М и ш и н Д.Е. Сакалиба (славяне) в исламском мире в раннее средневековье. М., 2002. *И.Л.Измайлов.*

**«СӘЛАМӘ́Т»**, яшелчә борчагы сорты. 2001 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында Т.Г.*Евдокимова*, А.Н.*Фадеева*, И.Н.Федотова тарафыннан чыгарыла. Сабагының озынлыгы 55–85 *см*, үсемлекнең буыннар саны 12–13, яфрагы һәм аның янындагы 2 парлы куе яшел тоташ читле яфракчыклары парсыз мыек б-н тәмамлана. Төпчек яфраклары куе яшел, ярым йөрәксыман, уртача зурлыкта, яфрак куентыгында антоциан түгәрәк юк. Чәчәк оешмасы — күп чәчәкле чук, чәчәкләре ак, эре. Чәчәк төбендә 2–4 кузак барлыкка килә (туры, уртача зурлыкта); кузагында 6 орлык (җыерчыклы, сары) була. Уртача өлгерешле, вегетация чоры 67–75 көн. Сөрлегүгә, авыруларга чыдамлыгы стандарт дәрәҗәдә. 1000 бөртекнең авырлыгы 195–200 *г*, протеин 24%, шикәр 6%. Бу сортның төп өстенлеге — яшел борчакның югары уңышы (1 *га* дан 35 *ц* га кадәр), сыйфаты 1 класслы стандартка туры килә. Техник өлгереш вакытында консервлау өчен үстерелә. Шәхси бакчаларда игелә. 2004 тә Урта Идел төбәге буенча, ш.и. Татарстанда селекция казанышларының Дәүләт реестрына кертелә.

**СӘЛАМӘТЛЕ́К САКЛА́У**, халыкның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, кеше гомерен озайтуга юнәлтелгән дәүләти, социаль-икътисади, җәмгыяви һәм мед. өлкәсенә караган чаралар системасы. С.с.ның төп бурычлары: халыкның сәламәтлек дәрәҗәсе торышын өйрәнү, авыруларны дәвалау һәм кисәтү; сәламәт тормыш һәм эш шартлары тудыруга юнәлтелгән сан.-эпид. һәм экология чараларын билгеләү; сәламәтлек саклау өлкәсендә кеше хокукларының саклануын, сәламәтлеген югалткан очракта, гражданнарның социаль яклануын тәэмин итү; амбулатор-поликлиника, стационар һәм санатор мед. ярдәме күрсәтүнең комплекслылыгын һәм өзeксезлеген тәэмин итү; физкультура һәм спорт б-н шөгыльләнү өчен шартлар тудыру; мед. деонтологиясе нормалары һәм кагыйдәләрен үтәү.

Татарстан терр-ясендәге табибләр һәм дәвачылар турындагы иң беренче мәгълүматлар Идел буе Болгар дәүләтенең элгәреге чорларына карый (9–10 йөзләр). Дәүләттә яшәүчеләр арасында табиблек гыйлеме таралуга Шәрекъ табиб-галимнәренең (Әбүгалисина һ.б.) хезмәтләре һәм гамәл-тәҗрибәләре б-н таныш булу, көндәлек тормышка мөселман йолалары кертелү этәргеч бирә. Дару үләннәре һәм аларны куллану ысуллары турында җирле белгечләрнең трактатлары күренә башлый (к. *Халык медицинасы*). Мәдрәсәләрдә дин гыйлеме б-н бергә дөньяви фәннәр, ш.и. табиблек гыйлеме нигезләре дә бирелә. Шәрекънең мәдәният-мәгърифәт үзәкләренә (Бохара, Сәмәрканд, Багдад һәм башка шәһәрләр) барып уку таралыш ала.

Дәүләт халык сәламәтлеген саклау системасы барлыкка килү 18 йөзнең беренче яртысына туры килә. 1776 елда табиблек идарәсе, җәмгыяви тәрбия приказлары (мохтаҗларга мед.-социаль ярдәм күрсәтү системасы) оеша, алар карамагында дәваханәләр һәм дәвалап булмый торган авырулар йортлары эшли башлый. Казанда беренче мед. стационары — хәрби госпиталь — 1809 да ачыла. 19 йөз уртасына Казандагы 175 ятак-урынлы губерна хастаханәсе (хәзер Карл Маркс урамындагы кардиология диспансеры), психик авырулар йорты, мохтаҗлар һәм караучысыз картлар йорты, никахтан тыш туган сабыйлар йорты һәм 3 ятимханә Җәмгыяви тәрбия приказы карамагында була. Губернадагы беренче хастаханәләр: Казан шәһәр хастаханәсе (1807), Спас хастаханәсе (1833), Казан ун-тының «Иске клиника»сы (1840), Чистай хастаханәсе (1844). 19 йөз уртасына, земство җирле үзидарәсе кертелү чорына, авыл җирендә 1,5 млн. кешегә 4 табиб һәм 46 фельдшер, 10 мең кешегә уртача 1,3 ятак-урын туры килә. Губерна халкы сәламәтлегенең торышы үлем-китем дәрәҗәсенең гаять югары булуы б-н билгеләнә. Казанда 1 мең кешегә 39,4 үлем очрагы туры килә, сабыйлар үлеме исәбе 100 балага 40 үлем очрагы тәшкил итә (1897 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча). Губерна халкының хәерчелеге һәм наданлыгы ш.у. йогышлы һәм «социаль чирләр» дип йөртелүче авыруларның киң таралуына сәбәп була. Авыл халкына мед. ярдәме күрсәтүнең земство үзидарәсе принципларына нигезләнеп оештырылуы респ-ка С.с. тарихында уңай күренеш буларак бәяләнә (к. *Земство медицинасы*). Төбәктәге мед. фәне һәм С.с. үсешендә, табиб кадрлар әзерләүдә 1814 тә Казан ун-тында мед. ф-ты ачылу әһәмиятле роль уйный. Беренче 15 ел эчендә 35 дәвалау белгече әзерләнә, 1917 гә кадәр 4493 табиб укытып чыгарыла. Казан ун-ты озак вакытлар буена Идел буе, Урал, Себер һәм Урта Азия өчен табиб кадрлар әзерләүче бердәнбер үзәк булып кала бирә. 1913 кә Казан губернасында 37 хастаханә, 46 фельдшерлык пункты исәпләнә, аларда 47 табиб һәм 171 урта мед. персоналы эшли. Гомуми үлем-китем дәрәҗәсе 1 мең кешегә 27,2 очракка кадәр кими, йогышлы авыруларга каршы көрәштә сизелерлек нәтиҗәләргә ирешелә. С.с.ны оештыру мәсьәләләре фәкать Окт. рев-циясеннән соң гына дәүләт дәрәҗәсендә хәл ителә башлый. Совет чорында тиз арада С.с. системасының төбәк идарә органнары төзелә. 1918 дә — Казан губернасы С.с. бүлеге, 1920 дә ТАССР С.с. Халык комис-ты (1946 дан — министрлык) оештырыла. Дәүләт үзәкләштерелгән С.с. системасын төзүгә нигез салына. 1920 дә Казанда 9 дәүләт хастаханәсе, Казан ун-ты һәм Клиник ин-т (1925 тән — ГИДУВ) клиникалары, хәрби госпиталь, округ психиатрия һәм тимер юл хастаханәләре, Эчке эшләр министрлыгы карамагындагы 2 хастаханә эшли (3 мең ятак-урын). Авыл җирендә 75 табиблек участогы исәпләнә, аларда 66 табиб хезмәт куя. Йогышлы авыруларга каршы фәнни тикшеренүләр, бактерия препаратлары һәм прививка материаллары җитештерү б-н Бактериология ин-ты (1900 дә нигезләнә) шөгыльләнә. 1920 дә ТАССР С.с. Халык комис-ты каршында 57 сан. табибен берләштергән сан.-эпид. хезмәте секциясе булдырыла (1917 гә кадәр Казанда 1 сан. табибе эшли, к. *Татарстан Республикасында санитария-эпидемиология хезмәте*). Совет медицинасының 1930 еллардагы казанышларын ваба, чәчәк, кайтма тиф авырулары, трахомага каршы нәтиҗәле чаралар күрү; аналар һәм балалар сәламәтлеген саклау системасы

булдыру, аналар һәм яңа туган балалар үлеме дәрәҗәсенең кимүенә китергән стационар акушерлык ярдәме оештыру тәшкил итә. Индустриальләштерү һәм крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү чорында сәнәгать һәм а.х. тармакларында эшләүчеләрнең сәламәтлеген саклау өлкәсендә чаралар күрелә; сәнәгать пр-тиеләрендә — мед.-сан. частьлары, колхоз һәм совхозларда С.с. пунктлары һәм бала тудыру йортлары булдыру эшенә керешелә. 1920–30 елларда Казанда Табибләр белемен күтәрү клиник ин-ты, Стоматология, Кан салу, Туберкулёз, Трахома, Татарстан ортопедия һәм травматология, Социаль сәламәтлек саклау һәм гигиена ин-тлары оештырыла. Казан ун-тының мед. ф-ты мөстәкыйль ин-т статусы ала (1930). 1935 кә авыл халкына мед. хезмәте күрсәтү радиусы 45 *км* дан 20 гә кала, бер хастаханәгә туры килүче авырулар саны 49 мең кешедән 17,3 меңгә кадәр кими. 1940 ка респ-кадагы хастаханәләр саны — 2, ятак-урыннар саны — 3,9, табибләр саны — 4,3, урта мед. персоналы саны 8,6 тапкыр арта. Бер үк вакытта махсус урта белем бирүче мед. уку йортлары челтәре (к. *Казан медицина көллияте, Казан медицина-фармацевтика училищесе*), санаторий-курорт ярдәме системасы (*«Иж минераль сулары»*, *«Бәкер»* курортлары, *«Казан»*, *«Крутушка»*, *«Васильево»* санаторийлары һ.б.) булдырыла. Йогышлы авыруларны кисәтүнең уңышлы алып барылуы төп демографик күрсәткечләрне күпкә яхшырта. 1940 ка респ-када гомуми үлем-китем очраклары күрсәткече 33,1 дән (1913) 26,4 кә, яңа туган балалар арасындагы үлем очраклары (1 мең тере туган балага) 340 тан (1913) 214,4 кә кадәр кими. Трахома, бизгәк авыруы (малярия), кызылча (скарлатина), корчаңгы бетерелә.

Бөек Ватан сугышы елларында ТАССР яралыларны дәвалау һәм тернәкләндерү үзәкләренең берсе була. Респ-када төрле профильдәге 59 эвакогоспиталь эшли (35 мең ятак-урын), аларда 350 меңнән артык яралы һәм авыру дәвалана, 200 меңнән артыгы кабат сафка баса, Татарстан ортопедия һәм травматология ин-тында дәвалануын дәвам итүчеләр дә күп була. Сугыштан соңгы елларда нефть чыгару сәнәгате алга киткән шәһәрләрдә С.с. структурасы актив үсеш ала. Зеленодольск, Чистай, Алабуга, Менделеев һәм башка район үзәкләрендә шәһәр һәм район хастаханәләре, поликлиника һәм мед.-сан. частьлары ачыла. 1960–70 еллар С.с. системасының матди-техник һәм кадрлар потенциалы нык үсү б-н характерлана. Сугыштан соңгы 20 ел эчендә респ-ка хастаханәләрендәге ятак-урыннар саны — 2 тапкыр (20,5 меңгә кадәр), табибләр саны — 2,8 тапкыр (4,6 меңгә кадәр), урта мед. персоналы саны 3 тапкыр (15,8 меңгә кадәр) арта. 1982 дә *Республика клиник хастаханәсе* (1210 ятак-урын), Балалар мед. үзәгенең (755 ятак-урын, к. *Республика балалар клиник хастаханәсе*) яңа биналары сафка басу, Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләрендә хастаханә учреждениеләре һәм тулаем 3635 ятак-урынлы 40 тан артык үзәк район хастаханәләре төзелү Татарстан С.с. тарихының мөһим сәхифәсен тәшкил итә. Санаторий һәм профилакторийлар челтәре киңәя (5150 урын). Авыл халкына мед. ярдәме күрсәтү күләме шәһәр дәрәҗәсенә җитә.

1970–80 елларда С.с. өлкәсендә яңа куәтләр файдалануга тапшырылмастан, хастаханәләрдә ятак-урыннар саны арту, мед. учреждениеләрен финанслау һәм техник яктан тәэмин итүнең түбән дәрәҗәдә булуы кебек тискәре күренешләр күзәтелә. С.с. системасына үзгәртеп корулар таләп ителә. 1990 елларда социаль-икътисади кризис шартларында туучылар саны кимү б-н бергә (1 мең кешегә — 13 очрак) үлем-китемнәр саны арта. Үлүчеләр арасында хезмәт яшендәгеләр 26% тәшкил итә. Хезмәт яшендәге ир-атлар үлеме хатын-кызлар б-н чагыштырганда 4 тапкырдан артык була. Туберкулёз, ВИЧ-инфекция, гепатит, наркомания, алкоголизм б-н авыру һәм үлем очраклары кискен арта. Әлеге вазгыятьне үзгәртү максатыннан ТРда стратегик үсеш юнәлешләре билгеләнә һәм «Татарстан Республикасы гражданнарының медицина иминияте турында» (1993), «Гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» (1998) законнары; ТР Президентының «Төбәкара клиник диагностика үзәге турында» (2000) Указы; ТР МКның «ТРның 1995–96 елларга яман шеш авыруларына каршы көрәш программасын раслау турында» (1995), «ТРда туберкулёз буенча эпидемиологик халәтне тотрыкландыру чаралары турында» (1998), «Татарстан балалары» республика программасы турында» (2002), «ТРда сәламәтлек саклау үсеше концепциясе турында» (2003) карарлары; «Эчәргә яраклы су» (1999), йогышлы авыруларга каршы 2001–05 елларга исәпләнгән вакцинацияләү һәм авыруларны кисәтү (1999) программалары һ.б. кабул ителә.

2003 кә ТР С.с. министрлыгының амбулатория-поликлиника учреждениеләре челтәре 102 мөстәкыйль поликлиника һәм амбулаторияне, хастаханә учреждениеләре составындагы 198 поликлиниканы, 36 диспансер һәм 28 стоматология поликлиникасын берләштерә. Дәвалау учреждениеләре план буенча сменага 10 мең кешегә 207,9 кеше исәбеннән кабул итү куәтенә ия, ягъни һәр кеше бер ел эчендә поликлиникага уртача 11,4 тапкыр мөрәҗәгать итә ала. Хастаханәләрнең ятак-урыннар б-н тәэмин ителү дәрәҗәсе 10 мең кешегә 94,7 кеше туры килә (респ-ка халкының 22,1% ы стационар ярдәм ала). Стационарлар һәм поликлиникалардагы көндезге дәвалану ятак-урыннарыннан ел дәвамында 100 меңгә якын авыру файдалана. 2003 тә ТР С.с. министрлыгы учреждениеләрендә 13 меңнән артык табиб, 50 меңгә якын урта мед. персоналы эшли. Белгечләр б-н тәэмин ителү дәрәҗәсе 10 мең кешегә 34,4 табиб һәм 104 урта мед. персоналы тәшкил итә. Табибләрнең — 55% ы, урта мед. персоналының 50% ы квалификация категориясенә, мед. хезмәткәрләренең 77% ы белгечлек сертификатына ия. Халыкка югары квалификацияле махсус мед. ярдәме күрсәтү эшендә ТРның югары уку йортлары һәм башка мед. фәнни уку-укыту учреждениеләре галимнәре актив катнаша. Респ-каның С.с. системасында 2 меңнән артык мед. фән. канд-ты һәм 220 мед. фән. д-ры хезмәт куя. Гамәли мед. өлкәсендә 300 гә якын мед. фән. канд-ты һәм 23 мед. фән. д-ры эшли. Мед. кадрларының югары проф. дәрәҗәсе Казан мед. академиясе һәм Казан мед. ун-тында системалы рәвештә белем күтәрү юлы б-н тәэмин ителә. Табибләргә дипломнан соңгы белем бирү 40 төр белгечлек буенча алып барыла. Казан мед. ун-тында респ-ка районнарыннан махсус юллама буенча ел саен 200 кеше укый. Дәүләт эпидемиология күзәтчелеге системасы 56 оешманы берләштерә, аларда 900 табиб һәм 1700 дән артык урта мед. персоналы эшли.

Респ-када күп укладлы фарм. базары эшчәнлек алып бара (Казанда — 33, респ-ка районнарында 31 аптека), дару матдәләре сатып алуны финанслау үзәкләштерелгән система буенча тормышка ашырыла. 2001 дә бер кешене дару матдәләре б-н тәэмин итү өчен бюджет һәм мәҗбүри мед. иминияте системаларыннан тотылган уртак чыгымнар уртача 216 сум тәшкил итә.

ТРда 3670 урынга исәпләнгән 9 санаторий һәм курорт («Васильево», *«Жемчужина»*, *«Ливадия»*, «Казан», «Бәкер», «Иж минераль сулары», «Крутушка», «Санта», «Сосновый бор»); көчле авырулардан соң өстәмә дәвалау, инвалид балалар, балаларны әти-әниләре б-н бергә кабул итү; йөкле хатыннар өчен тернәкләндерү бүлекләре булган, 3865 ятак-урынга исәпләнгән 40 санаторий-профилакторий эшли. Дәвалауда минераль сулар, дәва ләме (30 дан артык файдалы чыганак ачыкланган) киң кулланыла. Авыруларны өстәмә дәвалау 85% тан артык очракта аларның эшкә сәләтлелеген торгызырга һәм актив тормышка кире кайтарырга мөмкинлек бирә. Ел саен 50 меңнән артык кеше өстәмә дәва ала. Бу өлкәдә 80 нән артык табиб һәм 335 урта мед. персоналы хезмәт куя.

2014 елда респ-ка халкының уртача гомер озынлыгы 72,2 ел тәшкил итә. ТР халкының сәламәтлек торышын күрсәтүче төп күрсәткечләр (2013 ел, 1 мең кешегә): туучылар саны — 14,7, үлүчеләр саны — 12,1, 1 яшькә кадәрге балалар үлеме очраклары (1 мең исән туган балага) — 7,0.

Йогышлы авырулар структурасында иң зур күрсәткечләр грипп һәм кискен респиратор вируслы инфекцияләр (ОРВИ), паразитлар тарата торган авырулар, вируслы гипатит һәм социаль шартларга бәйле авырулар өлешенә туры килә. Респ-ка С.с. өлкәсе өчен авыруларны кисәтү мәсьәләләре, эчә торган суның, һаваның, азык-төлекнең сыйфатын яхшырту актуаль булып кала.

1990–2000 еллар заманча техника һәм җиһазлар б-н тәэмин ителгән мед. учреждениеләре сафка басу, югары технологияле төбәкара, респ-ка һәм шәһәр мед. үзәкләре барлыкка килү б-н характерлана. С.с. өлкәсендә заманча алдынгы дәвалау һәм диагноз кую, идарә итү технологияләре гамәлгә кертелә. 2010 еллардан ТР халкына беренчел мед.-сан. ярдәме күрсәтүне камилләштерү яңа көч б-н дәвам иттерелә. 2013 тә респ-каның 44 муниципаль җирлегендә 75 фельдшер-акушерлык

пункты, Казанның Нагорный бистәсендә амбулатория, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка онкология клиник диспансерында 57 ятак-урынлы радиология корпусы, Казан шәһәре 7 нче клиник хастаханәсе базасында 369 ятак-урынга исәпләнгән ашыгыч мед. ярдәме хастаханәсе, Казандагы Азино-1 микрор-нында дүрт катлы, сменага 280 авыру кабул итәрлек балалар поликлиникасы (№ 2–43) төзелеп, кулланышка тапшырыла. Татарстанда 4 мед. профилактикасы үзәге (Казан, Түбән Кама, Әлмәт, Яшел Үзән), шундый ук 19 бүлек, 116 кабинет бар; 66 балалар сәламәтлеге кабинеты, 760 «Сәламәтлек мәктәбе», балалар өчен — 6, өлкәннәр өчен 415 сәламәтлек үзәге исәпләнә. 2013 тә сәламәтлек саклау өлкәсендәге гамәли эшчәнлеккә респ-ка халкына, яшь буенча төркемләп, диспансеризация үткәрү тәртибе кертелә. Хәзерге вакытта ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы учреждениеләрендә 15 меңнән артык табиб, 40 меңнән артык урта мед. хезмәткәре эшли.

*Әд.:* Социальная гигиена и организация здравоохранения. М., 1998; Здоровье населения Республики Татарстан на пороге третьего тысячелетия. К., 1999; Т у л ь ч и н с к и й Т.Х., В а р а в и к о в а Е.А. Новое общественное здравоохранение: Введение в современную науку. Иерусалим, 1999; Здравоохранение Республики Татарстан. К., 2000; Статистика здоровья населения и здравоохранения (по материалам Республики Татарстан в 1996–2000 годы). К., 2001.

*И.Г.Низамов.*

**СӘЛАХЕТДИ́НОВ** Ришат Нәзахетдин улы (1.3.1963, Әлмәт ш.), монументалист, хаттат, нәкышьче, педагог. Чуаш пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тын тәмамлый (1986). 1988 елдан Чаллы шәһәрендә: пед. ин-тта укыта. 1989 да «Идегәй» фирмасына нигез сала һәм 1991 гә кадәр интерьерлар һәм мөселман кабер ташларын бизәү б-н шөгыльләнә. 1995–2002 дә 2 нче сәнгать мәктәбендә эшли. 2005 тән Казанда. 2007 дән Казан архит-ра-төзелеш ун-ты укытучысы. Мозаика, витраж, дивар бизәге һәм агачка, гипска уеп бизәк төшерү техникаларында татар мәчетләре интерьерларының декоратив-сәнгать бизәлеше авторы. Мөселман мәдәнияте традицияләрендә эшли, татар бизәлеш һәм хаттатчылык сәнгатен үстерә. 1990 да Мәккә һәм Мәдинәгә хаҗ кылып кайтуы С.ның иҗат юнәлешенә хәлиткеч йогынты ясый. Чаллы (1992 дән), Сургут (2001–08) шәһәрләрендә төзелүче җамигъ мәчетләренең интерьерлары һәм экстерьерлары авторы һәм бизәүчесе, Казандагы *Кол Шәриф* мәчетен бизәүдә (2000–05), Мәрҗани мәчете (2005), Әстерхан, Актүбә шәһәрләрендәге җамигъ мәчетләре (икесе дә — 2008), Башкортстанның Эстәрлетамак р-ны Кантюковка авылы мәчете (2008), Чистайдагы «Әнәс» мәчете интерьерларын реконструкцияләүдә катнаша. Гарәп язуын камил белә, *шәмаилләр*, *тугралар* иҗат итә. С. әсәрләре образ һәм текстның гармонияле синтезы, темалар, техник башкарулар (нәкышь, бронза, лак кулланылган графика) һәм кулланылган материалларның төрлелеге (киндер, картон, кәгазь, пыяла, агач, гипс) б-н аерылалар, бу аеруча «Тәүбә мәчете» (1995), «Болгар шәһәренә багышлау» (1966), «Икенде намазы» (1998, 2005), «Нух пәйгамбәр (с.г.в.)», «Гайсәгә багышлау», «Мөхәммәд Пәйгамбәргә багышлау» (барысы да — 2005) һ.б. шәмаилләрдә ачык чагыла. Пейзаж һәм натюрморт жанрларында нәкышь әсәрләре авторы.




Р.Н.С ә л а х е т д и н о в. «Мигъраҗ кичәсенә багышлана» шәмаиле. 1997.

Халыкара — «Идел-Урал» (Истанбул ш., Төркия, 1998); төбәк — «Зур Идел» (2000); «Идел буенда Ислам» (Казан, 2002), «Татар шәмаиле: сүз һәм образ» (Мәскәү, 2009) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Чаллы, Лениногорск (1998, Н.Исмәгыйлев б-н бергә), Казан (1999, 2000, 2013) шәһәрләрендә уздырыла.

Әсәрләре ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Чаллы картиналар галереясында, «Казан Кремле» тарих-архит-ра һәм сәнгать музей-саклаулыгының Ислам мәдәнияте музеенда, «Туран» милли мәдәният үзәге фондында, Россия, Төркия, АКШтагы тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Г а й н е т д и н о в а Ф. Аятьләрдән — галәмнәр // Аргамак. 1998. № 7; П о л я к о в а Л. Шамаили Рішата Саляхутдинова // Аргамак. 1998. № 2; Ш а м с у т о в Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле. К., 2003.

*Р.И.Шәмсутов.*



Р.Н.С ә л а х е т д и н о в. «Әнәс» мәчете гөмбәзе бизәге. Чистай ш.

**СӘЛА́ХОВ** Мәгъзүм Хәлимулла улы (13.7.1951, Казакъстан ССРның Кустанай өлкәсе Соколовка пос.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1992), проф. (1993), ТР ФА академигы (2004), ТРның һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (2004, 2007), Казан ун-тының атказ. профессоры (2011). 1973 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, оптика һәм нанофотоника каф. мөдире (1991 дән), проректор (2001–02), ректор (2002–10), Казан ун-ты президенты (2010–14). Бер үк вакытта, 2012–14 тә, ТР ФАнең физика, энергетика һәм Җир турында фәннәр бүлеге акад.-секретаре. ТР ФА президенты (2014 тән). Хезмәтләре гамәли спектроскопиягә карый. С. түбән темп-ралы плазмага һәм тузанлы фракталь структуралы плазмага спектроскопик диагностика ясау алымнарын



М.Х. Сәлахов.

эшли, бу алымнар спектраль сызыкларны штаркча киңәйтүнең фундаменталь константаларын билгеләүдә кулланыла. Спектроскопиянең күп үлчәнешле кайтма мәсьәләләрен анализлаучы бирелмәләрнең (фракталь тавыш, нәстационарлык, вакланма дәрәҗәле тренд һ.б.) махсус үзенчәлекләрен исәпкә алып чишү өчен регулярлаштыруның вейвлет-анализ һәм нейтрон челтәрләр куллануга нигезләнгән стат. алымнарын тәкъдим итә. Нанофотоника буенча фәнни юнәлеш булдыру инициаторы. Халыкара «Когерент оптика һәм оптик спектроскопия» яшьләр фәнни мәктәбе җитәкчесе (1997 дән). С. җитәкчелек иткән елларда Казан ун-тының төп бинасына көнбатыш ягыннан янкорма өстәп төзелә, нәтиҗәдә, әлеге архит-ра истәлеге 19 йөз осталары планлаштырган рәвешкә китерелә, башка биналарга реконструкция үткәрелә, ун-тның 200 еллыгы югары дәрәҗәдә билгеләп үтелә; психол. ф-ты һәм Химия ин-ты оештырыла, яңа кафедралар һәм белгечлекләр ачыла; «21 йөз материаллары һәм технологияләре» фәнни-укыту үзәге, Матдәләр һәм материалларны физик-химик тикшерүләрне күмәк куллану региональ үзәге төзелә; укыту процессына балл-рейтинг системасы кертелә; М.Т.Нужинга һәм Е.К.Завойскийга һәйкәл куела (икесе дә 2004 тә). ТР Дәүләт Советы депутаты һәм Президиумы әгъзасы (2004 тән). Россия ректорлары берлеге президиумы әгъзасы (2005–10). ТР Югары уку йортларының ректорлар советы рәисе (2005–10). «Учёные записки Казанского университета» басмасының баш мөхәррире (2005–10). Күптомлы Татар энциклопедиясенең Баш гыйльми мөхәрририяте әгъзасы (2006 дан). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010). Ломоносов исем. орден, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Уширение спектральных линий в плазме и газах. К., 1998 (автордаш); Математическая обработка и интерпретация спектроскопического эксперимента. К., 2001 (автордаш); Взаимодействие атомов с полем лазерного излучения и резонансная флуоресценция. К., 2013 (автордаш); Electron rest mass and energy levels of atoms in the photonic crystal medium // Phys. Rev. A., 2012. V. 85 (автордаш). Atherosclerotic plaque and hydroxyapatite nanostructures studied by high-frequency EPR // Magnetic Resonance in Solids. 2013. V. 15, № 1. (автордаш).

*Әд.:* Ректоры России. М., 2002.

**СӘЛА́ХОВ** Рабис Мөгаллим улы (10.12.1958, БАССРның Бүздәк р-ны Иске Актау а.), нәкышьче, гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы (керәч), дизайн остасы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2006), Уфа сәнгать уч-щесен тәмамлаганнан соң (1982), Алабуга район


башкарма ком-тының мәдәният бүлегендә рәссам булып эшли; Менделеев шәһәрендәге химия з-дында керәч җитештерүне сафка бастыра. 1985 елдан Татарстан сәнгать фондының Чаллы сәнгать-җитештерү участогында эшли, 1990 да ТР Рәссамнар берлегенең иҗат остаханәләрен оештыру өчен Алабугага күчерелә. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1994). Алабугадагы әйдәп баручы рәссамнарның берсе. Иҗат юлын керәчтән декоратив көнкүреш әйберләре ясаучы буларак башлый. Металл тозларын (көмеш, бакыр), маян, төсле ялтыравык кулланып, ирекле әвәләү һәм әүвәлге хәленә кайтаручы яндыру техникасында шамоттан һәм чүлмәк балчыгыннан эшләнгән уникаль күргәзмә декоратив савыт-сабалар, вазалар, тәлинкәләр, кувшиннар авторы: «Шәһәрлек», «Май киче», «Курай» кувшиннары (барысы да — 1992), «Суык су» (1986), «Болгар» (1987) комплектлары; диварга эленә торган монументаль-декоратив композицияләр: Уфа шәһәренең «Нефтьче» мәдәният сарае интерьерындагы «Күлләвек» рельефы, Алабуга бала тудыру йортындагы (1989), Китап йортындагы



Р.М.С ә л а х о в. «Суык су» комплекты. Керәч. 1984. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

(1990) «Ел фасыллары» рельефлары; Алабуга балалар бакчалары интерьерларындагы күләмле-фәзаи композицияләр һәм декоратив вазалар (1988, 1992), Алабугадагы җамигъ мәчет фасады өчен бизәкле чынаяк кирпеч (кулдан эшләнгән гипс калыбы, 1993).

1980 еллар ахырыннан күбрәк тематик жанрдагы станлы нәкышь өлкәсендә нәтиҗәле эшли, максатына ирешүдә татар халык сәнгатендәге колоритлы һәм декоратив системалардан, фольклор образы символларыннан файдалана. Төп әсәрләре: «Даруханә» (1989), «Борынгы шәһәр» (1993), «Чишмә башы» (1996), «Япанчы. Дала сакчысы», «Ханзадә алмасы» (икесе дә — 2002); күчмә сәнгать күргәзмәсе өчен «Күчмә төргәкләр — habar» сериясе (2006), «Алабуга легендасы» (2007) картиналар сериясе, «Дала җыры», «Кызлар тавы» (икесе дә — 2009). Соңгы елларда С., дизайнер буларак, Алабугадагы М.Цветаева әдәби музее (2005), Н.Дурова музей-утары (икесе дә — 2006), Туган якны өйрәнү музей комплексы, В.Бехтеров исем. өяз медицинасы музее (икесе дә — 2007), сәнгать галереясы (2008), Арчадагы «Казан арты» тарих-этнография музее (2009) интерьерларын бизи. Алабуга җамигъ мәчетенең намаз залы интерьерын, Алабуга шәһәре терр-ясен гомуми төзекләндерү проектлары авторы.



Р.М.С ә л а х о в. «Саз». «Сәйф Сараи» сериясеннән. Картон. темпера. 2005.

Респ-ка (1982 дән), бөтенроссия — «РСФСРның 16 автономияле республикасы» (Мәскәү, 1971), «Алтын палитра» (Саратов ш., 2007), бөтенсоюз — «Рәссамнар — халыкка» (Мәскәү, 1986), бөтентатар — «Татарт» (С.-Петербург — Казан, 1991), халыкара — «Күчмә төргәкләр — habar» (Мәскәү, Әнкара, Конья ш., Казан; 2006–07) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәсе Казанда 2008 елда оештырыла. С. әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Алабуга тарих-архит-ра һәм сәнгать музей-саклаулыгында, Болгар тарих-архит-ра музей-саклаулыгында, шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Ш а һ и е в а Р. «Кызыл матәм» // Казан утлары. 2004. № 10; С у л т а н о в а Р.Р. Искусство новых городов Республики Татарстан. К., 2001; Рабис Саляхов: Буклет к персональной выставке. К., 2008; Ф а д е е в Г. Сказочник из Елабуги // Рампа. 2008. № 12.

**СӘЛА́ХОВ** Рәсимҗан Салихҗан улы (10.5.1938, БАССРның Илеш р-ны Җәйләү а. — 10.7.2006, Казан), драма актёры, ТРның халык артисты (1998). 1961 елда Казан Зур драма театры каршындагы студияне тәмамлый һәм Татар акад. театры труппасына кабул ителә. С. — мөлаемлыгы б-н аерылып торучы актёр, ул сәхнә персонажларының эчке дөньяларына карата бик игътибарлы һәм сизгер. Истә калырлык, тирән эчтәлекле



Р.С.С ә л а х о в Мөәзин ролендә («Казан сөлгесе», К.Тинчурин; Әсма ролендә – Д.Н.Нуруллина).



Р.С.Сәлахов.

образлар иҗат итә: чиксез күтәренке рухлы, ярым тиле Тугыш; елгыр күзле, елдам ялагай Җомадил («Һиҗрәт», «Портфель», Н.Исәнбәт), бозык, оятсыз Хафиз («Мирас», Г.Каюмов), үз-үзенә ышанычын югалткан композитор Фәһим («Хушыгыз!», Т.Миңнуллин) һ.б. Яшертен, һәрвакыт бераз сагаючан Наил («Туй алдыннан», Х.Вахит), шаян, шук, эчкерсез авыл егетләре Рәдиф һәм Марат («Җиргә тапшырылган серләр», «Әңгер-меңгер», А.Гыйләҗев) кебек яшьтәшләрен уйнап, актёр һәркайсында кабатланмас, үзенә генә хас сыйфатларны табарга омтыла. С. ш.у. Хаммат, Бики («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Зөфәр («Зөбәйдә — адәм баласы», Ш.Хөсәенов), Витя («Бер төн», Б.Л.Горбатов), Ибраһим («Казан сөлгесе», К.Тинчурин), Баязит («Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз», И.Юзеев), Хәлим («Карак», З.Хәким), Юныс («Шәҗәрә», Т.Миңнуллин), Әхмәтсәгыйр («Алдым-бирдем», Г.Исхакый), Кузьма («Авылдашлар, акча кирәк!», В.Распутин) рольләрен уңышлы башкара.

*Әд.:* И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005.

*И.И.Илялова.*

**СӘЛА́ХОВ** Рәшит Ислам улы (17.12.1941, Апас р-ны Иске Борнаш а.), хокук белгече, ТРның, РФнең атказ. юристы (1998, 1999). Казан ун-тын тәмамлый (1972). 1962–64 елларда ВЛКСМның Красноуфимск шәһәр ком-ты инструкторы (Свердловск өлкәсе). 1964–73 тә 10 нчы төзү-монтаж идарәсе 2 нче Казан трестында, 1969 дан ВЛКСМ ком-ты секретаре. 1973–86 да ТР Югары мәхкәмәсе әгъзасы, 1993–96 да — рәисе урынбасары. 1986–93 тә Казанның Совет р-ны халык мәхкәмәсе рәисе. 1996–2001 дә ТРның Югары арбитраж, 2001–2011 дә — Арбитраж мәхкәмәләре рәисе. Дуслык ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**СӘЛӘНГЕ́Ш** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Олы Сөлчә елгасының (Олы Чирмешән бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 21,6 *км*, бассейнының мәйданы 148,5 *км*$^2$. Идел аръягы түбәнлеге буйлап, Нурлат р-нында ага. Елга башы урман массивы кырыенда, Сәләнгеш авылыннан 7 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Мамык авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 72 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 75%. С.нең 1 дән 11,9 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар, аеруча зурысы — Бәрле (уң кушылдык) елгасы. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,41 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпеллык катламы 103 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март

ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,12 *м³/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. С. бассейнында суының гомуми күләме 2,6 млн. *м³* булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.


**СӘЛӘНГЕ́Ш** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 39 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сәләнгеш елгасы буенда. 2010 елда 601 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710 нан (рус чыганакларында) Починок по речке Селенгуш исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Деяшева буларак та мәгълүм. Башта татарлар яши, 18 йөзнең 2 нче яртысында руслар урнаша башлый. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тәгәрмәч тугымы ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.тә Успение чиркәве (1868 дә төзелә), чиркәү-приход мәктәбе (1885 тә ачыла), 3 тимерчелек, 1 шәраб һәм 9 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2221 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Әлмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 67 ир-ат; 1859 да — 952, 1897 дә — 1760, 1908 дә — 2338, 1920 дә — 2114, 1926 да — 1664, 1938 дә — 1486, 1949 да — 1334, 1958 дә — 924, 1970 тә — 956, 1979 да — 761, 1989 да — 558, 2002 дә — 641 кеше.

**СӘЛӘНГЕ́Ш** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 12 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 1 кеше (рус) яши. 1740 елларда алпавыт Диштрополевлар нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ивановский, Бутырки исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Иоанн-Предтеча чиркәве (1763 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1871 дә ачыла), 4 ашлык саклау-сату кибете, тимерчелек, казна шәраб һәм вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 457,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Сәләнгеш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч районында. Халык саны: 1782 дә — 66 ир-ат; 1859 да — 357, 1897 дә — 485, 1908 дә — 369, 1920 дә — 468, 1926 да — 429, 1949 да — 293, 1958 дә — 241, 1970 тә — 166, 1979 да — 10, 2002 дә — 1 кеше.

**СӘЛӘ́Х** Сәгыйть Галим улы (2.9.1932, Сеул ш.), атом энергетикасы өлкәсе галиме, атом инженериясе фән. д-ры (1964). 1954 елдан АКШта яши. 1964 тә ун-т тәмамлаганнан соң (Флорида штаты), АКШның Атом энергетикасы комиссиясе хезмәткәре (Бетесда ш., Мэриленд штаты). 1966–70 тә — Атом үзәге (Лардже ш.), 1970–73 тә Вистингауст атом энергетикасы системасы (Питсбург ш., Пенсильвания штаты) инженеры. 1973–93 тә АКШның атом энергиясе куркынычсызлыгы һәм аны контрольдә тоту буенча Дәүләт комиссиясе әгъзасы (Бетесда ш.). Хезмәтләре атом энергетикасы, атом электростанцияләре өчен реакторлар җитештерү һәм аларның куркынычсызлыгы мәсьәләләренә карый.

**СӘЛӘХЕТДИ́НОВ** Гадел Касыйм улы (23.12.1928, Минзәлә кантоны Каратай-Саклау а.), галим агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. агрономы (1961). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), Сарман р-нының Алга МТСнда баш агроном булып эшли. 1958–63 елларда «Мөслим» с-зы директоры, 1963–91 дә Актаныш р-нының «Кызыл Көч» к-зы рәисе. С. җитәкче булганда, «Кызыл Көч» к-зында 60 тан артык җитештерү объекты һәм мәдәният-көнкүреш биналары төзелә. 1963–90 да бөртекле ашлык җитештерү — 2,2 тапкыр, ит — 2,1, сөт — 2,9, бөртеклеләрнең уңышы — 2,7, еллык савым һәр сыердан уртача 2 тапкыр арта. Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**СӘЛӘХЕТДИ́НОВ** Гарәфетдин Сәләхетдин улы (1.2.1920, Самара губ., Бөгелмә өязе Тайсуган а. — 19.12.1975, Ташкент), Дан орденының тулы кавалеры (25.8.1944, 1.2.1945, 27.6.1945), гв. старшинасы. Туган авылында колхозда эшли. 1942 елның мартыннан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең апреленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 54 нче гв. танк бригадасында зенит-пулемёт ротасының пулемёт төзәүчесе (3 нче танк армиясенең 7 нче гв. танк корпусы). Үзәк, Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Орёл (1943), Львов-Сандомир (1944) һәм Түбән Силезия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 20 августында Сандомир (Польша) шәһәреннән көнбатыштарак барган сугышта батырлык күрсәтә: дошман авиациясе һөҗүме вакытында «Юнкерс-87» бомбардировщигын бәреп төшерә, яралана, әмма пулемёттан атуын дәвам итә; 1945 нең 16 гыйнварында Ченстохова (Польша) шәһәре янында бригаданың хәрби һөҗүме вакытында «Фокке-Вульф-190» истребителен бәреп төшерә; гаскәр шәһәргә таба юнәлгәндә зенит уты б-н дистәгә якын гитлерчыны юк итә; 1945 нең 20–22 апрелендә Дрезден (Германия) шәһәре юнәлешендә хәрәкәт итүче танк колоннасы һөҗүме вакытында кыска пулемёт уты б-н «Фокке-Вульф-190» самолётын яндыра, дистәдән артык пехотачыны юк итә, расчёт б-н бергәләп дошманның күпләп солдатын әсир ала. 1945 тә демобилизацияләнгәннән соң, туган ягына кайта. 1947 дә Узгарыш кышлагына (Ташкент өлкәсе Калинин р-ны) күчеп китә, колхозда эшли. Медальләр б-н бүләкләнә. С. исеме б-н Ташкент шәһәренең бер урамы атала.



Г.С. Сәләхетдинов.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СӘЛӘХЕТДИ́НОВ** Фәрид Закир улы (26.2.1930, Казан), тарихчы, тарих фән. канд. (1970), проф. (1972). 1951–53 елларда ВЛКСМның Сәмәрканд шәһәр ком-ты 1 нче секретаре. Сәмәрканд ун-тын тәмамлаганнан соң (1953), Сәмәрканд мед. ин-тының марксизм-ленинизм каф.нда укыта. 1972 дән Сәмәрканд архит-ра-төзелеш ин-тының филос. каф. мөдире. Хезмәтләре Үзбәкстанда яшьләр хәрәкәтенә, Сәмәрканд өлкәсе партия һәм комсомол оешмалары тарихына карый; Советлар Союзы һәм Соц. Хезмәт Геройлары турында очерклар авторы.

Х е з м.: Звёзды Самарканда. Самарканд, 1968; История Самарканда. Самарканд, 1970 (автордаш).

**СӘЛӘХЕТДИ́НОВА** Мөнирә Газыйм кызы (20.4.1920, Түбән Новгород губ. — 21.12.1990, Ленинград), филолог, шәркыятьче галим, филол. фән. канд. (1955). Ленинград ун-тын тәмамлый (1949). 1954 елдан СССР ФА Көнчыгышны өйрәнү ин-тының Ленинград бүлекчәсендә, фарсы кулъязмалары каталогын төзи. Фәнгә кулланылышка 16–18 йөзләр фарсы чыганакларын, ш.и. Сәмәндәр Термезинең «Дастур әл-мөлек» («Патшаларга үгет»), «Дәфтәре Чыңгызнамә»нең вариантларын кертә, Хафиз Таныш Бохаринең «Шәрәфнамәсе — шаһи» хезмәтен («Шаһ даны китабы», 1–2 т., М., 1983–89) тәрҗемә итә. С. хезмәтләре б-н Россия шәрекъ белеме үсешенә, төрки халыкларның тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертә. «Кыргызлар һәм Кыргызстан тарихыннан материаллар» («Материалы по истории киргизов и Киргизии», М., 1973) җыентыгы авторларының берсе.

Х е з м.: Об одном неизвестном персидском сочинении по истории народов Поволжья // Страны и народы Востока. 1965. Вып. 4; Персидские и таджикские рукописи Института народов Азии АН СССР: Краткий алфавитный каталог. Л., 1964. Ч. 1 (автордаш).

*И.Л.Измайлов.*

**СӘЛӘХИ́ЕВ** Фәнис Мөдәррис улы (5.5.1966, Киров өлкәсенең Малмыж өязе Иске Ирек а.), спортчы (авыр атлетика — гер күтәрү спорты), Россиянең атказ. спорт остасы (2000). Киров пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1992). Армия СКнда тәрбияләнә (Ленинград, тренеры — Р.З.Зиннәтов). Россия (1994, 1996–99, 2001–02, ике төр ярыш; 2005, хәрәкәтләрнең аерым төрләре), Европа (2002, озын цикл), дөнья (1993–94, 1996–2002, 2004, ике төр ярыш; 1999, озын цикл) чемпионы; Россия Кубогы (1993–94, дөнья Кубогы (1994, 1998) иясе. 1988–1992 дә — Киров өлкәсе, 1993–2005 тә ТР җыелма командасына керә. Дөнья рекордчысы (1993, 1996–97, 2000, 2004). 1987–89 елларда «Электрон» СКнда авыр атлетика бу-

енча тренер (Киров өлкәсенең Вятка Аланы). 1989 дан хәрби хезмәттә.

**СӘЛӘ́ХОВ** Әнәс Сәләх улы (1.9.1923, Спас кантоны Әҗмәр а.), педагог, ТАССР, РСФСРның атказ. мәктәп укытучысы (1953, 1974), СССРның халык укытучысы (1980). Спас пед. уч-щесен (1941), Казан пед. ин-тын (1951) тәмамлый. 1941 елдан Ямбакты җидееллык мәктәбендә, 1944 тән Спас р-нының Әҗмәр җидееллык, соңрак унъеллык мәктәбендә, 1968 дән Казанның 68, 55, 13 нче мәктәпләрендә директор; 1988–2002 дә Казанның 130 нчы өстәмә белем бирү мәктәбендә педагог.

*Әд.:* К а р т а ш о в а Л.Б. «И не было добрее Вас и строже» // Спасские сказания (Из прошлого и настоящего города Болгар и Спасского района Татарстана). К., 2003.


**СӘЛӘ́ХОВ** Миргазиян Сәләх улы (20.5.1928, Минзәлә кантоны Иске Байсар а.), зоотехник, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССР, РСФСРның атказ. зоотехнигы (1975, 1990). Минзәлә а.х. техникумын тәмамлый (1970). 1945–88 елларда Мөслим р-нында эшли: Иске Байсар авыл советы секретаре, КПСС район ком-ты инструкторы (1948 дән), «Урожай» к-зы рәисе (1955 тән). С. җитәкче булганда, «Урожай» к-зында ат, дуңгыз, сарык фермалары, урта, сигезьеллык һәм башлангыч мәктәпләр, 3 мәдәният сарае, 3 балалар бакчасы һәм җитештерүдә башка объектлар, социаль-мәдәният һәм көнкүреш биналары төзелә. Колхоз ел саен 40–45 мең *ц* бөртекле ашлык, 55–60 мең *ц* шикәр чөгендере, 6–7 мең *ц* бәрәңге, 7 мең *ц* ит, 30 мең *ц* сөт, 300–500 мең данә йомырка сата. Бөртекле ашлык уңышы 1 *га* дан 33 *ц* га, еллык савым һәр сыердан уртача 4400 *кг* га җитә. 1967–71 дә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Октябрь Рев-циясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**СӘЛӘ́ХОВ** Фирдинант Абдулла улы (1.1.1956, Апас р-ны Чүри-Бураш а.), җырчы (лирик тенор), ТРның халык артисты (1999). 1986 елда Казан консерваториясен (З.Хисмәтуллина классы) тәмамлый. 1981 дән ТАССРның Дәүләт Җыр һәм бию ансамбле артисты, 1987 дән Татар опера һәм балет театры солист-вокалисты, 1990 нан Татар филармониясе солисты, 1995 тән ТР Композиторлар берлеге солисты. Татар вокал сәнгатенең күренекле җырчыларыннан берсе. Яхшы тавышка, югары башкару культурасына, зур осталыкка, сәхнә мөлаемлыгына ия. С.ның җентекле сайланган репертуарына милли классиканың иң яхшы үрнәкләре һәм әйдәп баручы хәзерге композиторларның әсәрләре керә. ТР композиторларының иҗатын пропагандалауда актив катнаша. Россия шәһәрләрендә, БДБ илләрендә, чит илләрдә чыгышлар ясый; аның башкаруындагы җырлар радио һәм телевидениедән трансляцияләнә. Р.Ваһапов исем. 4 нче Халыкара татар җыры фестивале режиссёры (2007). Халыкара «Татар җыры — 91» конкурсы, Халыкара дөнья халыклары җырлары конкурслары (Тунис, 1997) лауреаты; «Поющая Россия» конкурсы дипломанты (1995).

**СӘЛӘ́ХОВА** Җәваһирә Сәләх кызы (1.10.1925, Арча кантоны Түбән Кенә а. — 24.12.2009, Мәскәү; Казанда җирләнә), җырчы, ТАССРның атказ. артисты (1957). 1939–42 елларда Казан музыка уч-щесенең вокал бүлегендә укый. 1941 дә ТАССРның Җыр һәм бию ансамблендә, 1942–66 да Татар филармониясе солисты. Бөек Ватан сугышы елларында фронт концерт бригадасы составында эшли. 1957 дә Мәскәүдә Татар сәнгате һәм әдәбияты декадасында катнаша. Актив концерт эшчәнлеге алып бара. Радио һәм телевидениедә чыгышлар ясый, Татарстанда, СССР респ-калары һәм өлкәләрендә гастрольләрдә йөри. Җырчының репертуарын, башлыча, татар халык җырлары («Галиябану», «Зөләйха», «Мәрфуга», «Зиләйлүк», «Тәфтиләү» һ.б.), Татарстан композиторларының (С.Сәйдәшев, М.Мозаффаров, Җ.Фәйзи, Н.Җиһанов һ.б.) җырлары һәм операдан, муз. комедияләрдән арияләр; башкорт халык җырлары, башкорт композиторларының вокаль әсәрләре тәшкил итә. Бигрәк тә илһамланып һәм ихлас күңелдән борынгы татар халык көйләрен башкара. С.ның тавышы тулы яңгырашлы, иркен сулышлы, ачык тембрлы булуы б-н аерылып тора, башкаруына күтәренке рух, тотнаклылык, сәхнә нәзакәтлелеге, тыңлаучылар күңеленә юл таба белү хас. Татар халкының җыр мирасын пропагандалауга күп көч куя. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



Җ.С. Сәләхова.



Ф.А. Сәләхов.



Г.З. Сәлимҗанов.

**СӘЛИ́ЕВ** Госман (19 йөз ахыры — 20 йөз башы), хаттат, шәмаилләр авторы. Казанда эшли (Иске Татар бистәсендәге остаханәләрнең берсендә дип фараз ителә). С. имзалаган 2 *шәмаил* сакланган: «Аллаһ — саклаучыбыз һәм шәфкатьледән шәфкатьлесе» (шәхси тупланмаларда), «Хактыр ки, без сиңа бәхәссез җиңү бүләк иттек» (Коръәндәге «әл-Фатыйха» сүрәсенең беренче аяте; ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана). Алар 20 йөз башында эшләнгән; татар шәмаилләренә хас рәвештә пыялада майлы нәкышь техникасында гарәп язуы б-н башкарылган, нәфис агач рамга куелган. Шәмаилләр этикеткасының берсенә: «Казаннан кятиб Госман Сәлиев» дип язылган. «Нәсх» алымында башкарылган өзлексез, эре хәрефле гарәп язуы шәмаилнең барлык өслеген диярлек били, арткы ягыннан аңа бөгәрләнгән алтынсу фольга түшәлгән, ул төп кара фонда аерылып тора. Фонның һәм язуларның болай ярашуы *Кәгъбә* диварларына ябылган алтын-көмеш чигүле кара тукыма-кыйсваны хәтерләтә. Беренче шәмаилдә гарәпчә Коръән формуласы купшы үсемлек сабагына охшатып бизәлгән кыса б-н каймаланган. С. шәмаилләренең композициясе һәм башкару техникасы ш.у. пыялага майлы нәкышь алымы б-н ясалып, астына фольга түшәлгән Коръән язуы — төрек җамалтысы б-н туры килә.



Г. С ә л и е в. «Аллаһ – саклаучыбыз һәм шәфкатьледән шәфкатьлесе» шәмаиле. Пыяла, майлы буяу, фольга. 20 йөз башы.

*Әд.:* Ш а м с у т о в Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле: от прошлого до настоящего. К., 2003.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*


**СӘЛИ́М әс-САБАВЫ́Й** (?, Казан губ., Мамадыш өязе Байлар Сабасы а. — 1808, Бохара ш.), дин эшлеклесе, илаһият галиме. Байлар Сабасы авылы мәдрәсәсендә укыта. 1773–74 елларда Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге *крәстияннәр кузгалышында* катнаша, баш күтәрүчеләр хәрәкәте бастырылгач, Бохарага кача. ***Фикъһ*** — мөселман хокукы, мөселманнарның үз-үзләрен тотышының әхлакый һәм юридик нормалары мәсьәләләренә караган әсәрләр авторы.

*Әд.:* М ә р җ а н и Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

**СӘЛИМҖА́НОВ** Галимҗан Закирҗан улы (1.9.1923, Чистай кантоны Яңа Үзи а. — 19.12.2005, Казан), аппаратчы, Соц. Хезмәт Герое (1971). Тракторист-машинистлар курсын тәмамлаганнан соң, 1940–42 елларда Аксубай р-нының Иске Тимәш МТСнда эшли, 1944–96 да «Нәфис» АҖдә: генераторчы, өлкән аппаратчы. Новатор, рационализатор. Майларны тирән гидрогенизацияләү технологияләрен һәм яңа техниканы үзләштерүдә катнаша. Герой исеме 8 нче бишьеллык (1966–70) планны үтәгәндә ирешкән уңышлары өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980. Кн. 1; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**СӘЛИМҖА́НОВ** Марсель Хәким улы (7.11.1934, Казан — 26.3.2002, шунда ук), драма актёры, режиссёр, педагог, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1969, 1975), РСФСР һәм СССРның халык артисты (1980, 1984), ТР ФА академигы (2001). Артистлар Х.Й.*Сәлимҗанов* һәм Г.Н.*Нигъмәтуллина* гаиләсеннән. 1957 елда — Казан ун-тының юридик ф-тын, 1962 дә Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тының (ГИТИС) режиссёрлык ф-тын (А.М.Лобанов һәм А.А.Гончаров курсы) тәмамлый. Татар акад. театры сәхнәсендә А.Н.Островскийның «Котырган акчалар» («Бешеные деньги») пьесасы буенча диплом спектаклен куя. Шул ук елда Казан яшь тамашачылар театрына (ТЮЗ) сәхнәгә куючы-режиссёр буларак чакырыла. Беренче сезонда ук аның сәхнәсендә 3 спектакль куя: «Кояш үрелмәсе» («Солнечное сплетение», А.Г.Зак, И.К.Кузнецов), «Замана балалары» («Современные ребята», М.Ф.Шатров), «Гавана малайлары» («Мальчишки из Гаваны», В.М.Чичков). Алар конфликтның кискенлегенә, мизансценалар динамикасына нисбәтле рәвештә заманча яңгыраш ала. 1964 тә Казан ТЮЗының сәнгать җитәкчесе була. Бу чорда куелган спектакльләр («Бирнәсез кыз» — «Бесприданница», А.Н.Островский; «Бер төн» — «Одна ночь», Б.Л.Горбатов; «Алар һәм без» — «Они и мы», Н.Г.Долинина) тамашачы һәм тәнкыйть тарафыннан югары бәяләнә. Бер үк вакытта актёр да була: Адольфо («Гавана малайлары», В.М.Чичков), Генелон («Тристан һәм Изольда», А.Я.Бруштейн), Коллен («Чылбыр белән богауланганнар», Н.Дуглас, Г.Смит), Карабанов («Мулланур Вахитов», Н.Исәнбәт) рольләрен оста башкара. 1966 дан Татар акад. театрының баш режиссёры. С. тарафыннан Н.Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу», Э. де Филиппоның «Бәйрәм кичендә» («Рождество в доме синьора Купьелло», икесе дә — 1966) пьесалары буенча куелган беренче спектакльләрдә кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләр, тормышның заманча агышы искиткеч дөрес гәүдәләндерелә. «Хуш, Назлыгөл» («Дуэль», М.Байҗиев; 1968), «Әни килде» (Ш.Хөсәенов; 1970), «Бер төн» («Одна ночь», Б.Л.Горбатов; 1974) спектакльләрендә сәхнә образларының тормышчанлыгына тирән психол. анализ ысулы б-н ирешелә. С. куйган «Диләфрүзгә дүрт кияү» (Т.Миңнуллин; 1972), «Әнә килә автомобиль» (Ф.Яруллин; 1974) спектакльләренә



М.Х.Сәлимҗанов.

водевильчә җиңеллек хас. К.Тинчуринның «Американ» (1969) комедиясен С. көчле гротеск жанрында куя; шул ук авторның «Сүнгән йолдызлар» (1971) мелодрамасы аның куюында сугышка карата көчле нәфрәт хисе гәүдәләнеш алган эпик әсәргә әверелә. К.Тинчуринның «Назлы кияү» (1975), «Казан сөлгесе» (1982) пьесалары буенча куелган спектакльләр комедия рухы б-н сугарылган. 1970, 1977, 1987, 2000 елларда С. К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» мелодрамасына мөрәҗәгать итә. Һәр куелышта әлеге спектакль режиссёр тарафыннан яңача укыла һәм камилләшә барган кебек тәэсир калдыра. Т.Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» (1976), «Моңлы бер җыр» (1981), А.Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» (1987) әсәрләре буенча куйган спектакльләрдә режиссёр, сәхнәдәге метафорик шартлылык б-н тормышчан дөреслекнең табигый үрелешен тәэмин итеп, тормыш фәлсәфәсенең төп чыганакларын ачып бирә, фаҗигаи-полифоник яңгырашка омтыла. Әлеге спектакльләр театр сәнгатендә күренекле урын тота, режиссёр иҗатының уңышын билгели. Рус һәм чит ил классик әсәрләре буенча куелган «Агай-эне — ак мыек» («Свои люди — сочтёмся», А.Н.Островский; 1972), «Бирнәсез кыз» («Бесприданница», А.Н.Островский; 1983), «Җимерелгән бәхет» («Светит, да не греет», А.Н.Островский; 1993), «Ике хуҗаның хезмәтчесе» («Слуга двух господ», К.Гольдони; 1991), «Гаугалы гаилә» («Суббота, воскресенье, понедельник», Э. де Филиппо; 1999) спектакльләре үзләренең үзенчәлекле укылышлары, заманча яңгырашлары б-н аерылып торалар. Татар акад. театрында 70 тән артык спектакль куеп, ш.и. Т.Миңнуллинның 17 пьесасын, А.Гыйләҗев, Ш.Хөсәенов, Х.Вахит, Р.Ишморат, яшь татар драматургларыннан Р.Хәмид, Ю.Сафиуллин, З.Хәким, М.Гыйләҗев, Р.Зәйдулла һ.б.ның әсәрләрен сәхнәләштереп, С. татар театрының заманча драматургиягә нигезләнгән төпле репертуарын булдыра. Татар театры классикларына мөрәҗәгать итеп, С. аларның әсәрләренең алыштыргысыз кыйммәтен күрсәтә. Режиссёрның рухы, сәнгатьчә чаралар һәм жанрлар төрлелеге ягыннан үтә заманча иҗаты татар театры сәнгатен баета, аны дөнья театры киңлегенә чыгара, алга таба үсеш юлларын билгели. С. ТРның башка театрлары сәхнәләрендә дә спектакльләр, теле- һәм радиоспектакльләр куя, массакүләм театральләштерелгән тамашалар һәм концертларда режиссёр буларак чыгыш ясый. 1964 тән — Казан театр уч-щесендә, 1990 нан Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында укыта, проф. (1992). ТАССРның Г.Тукай исем., РСФСРның К.С.Станиславский исем. Дәүләт бүләкләре (1971, 1979), РФ Театр эшлеклеләре берлегенең «Алтын битлек» милли бүләге (2001) лауреаты. Дуслык ордены б-н бүләкләнә. С. истәлегенә Татар акад. театры фойесында бронза бюсты, Актёрлар йортына истәлекле такта куела. 2014 тә ТРда М.Сәлимҗанов исем. Респ-ка бүләге булдырыла.

*Әд.:* Марсель Сәлимҗанов: Мәкаләләр, әңгәмәләр, истәлекләр, мәзәкләр. К., 2004; Илялова И. Театр имени Камала. К., 1986; шул ук. Марсель Салимжанов. К., 1993; Марсель Салимжанов. Линия судьбы. К., 2004.

*И.И.Илялова.*

**СӘЛИМҖА́НОВ** Рафис Хәсән улы (1.10.1952, Тукай р-ны Иштирәк а.), язучы. Казан ун-тын тәмамлый (1975). 1977 елдан Зәй шәһәрендә яши, район комсомол ком-тында инструктор, «Дуслык байрагы» г-тасында әдәби хезмәткәр. 1979 дан Чаллыда: «Таң йолдызы» г-тасы һәм «Аргамак» ж-лы редакцияләрендә эшли. 1992–2006 да «Мәгърифәт» китап нәшрияты директоры. С. иҗатына фәлсәфи уйланулар, юмор хас. «Елан мөгезе» (1984) исемле юмористик хикәяләр җыентыгында алдакчы, зәвыксыз, беркатлы авыл кешеләреннән көлеп язган әсәрләре тупланган. «Күкеле сәгать» (1986) җыентыгы балаларга атап язылган. С. ш.у. «Акъярдагы ахырзаман» комедиясе (Минзәлә татар драма театры 1988 дә сәхнәгә куя), «Амбар кенәгәсе» (1989) исемле роман авторы. Публицистик мәкаләләре татар милли үзаңы үсеше мәсьәләләренә карый.


**СӘЛИМҖА́НОВ** Хәким Йосыф улы (25.2.1903, Оренбург губ. Орск ш. — 11.11.1981, Казан), драма актёры, режиссёр, ТАССРның халык артисты (1957). М.Х.*Сәлимҗановның* әтисе. Сәхнә эшчәнлеген 1919 елда Орск шәһәрендәге татар театрында башлап җибәрә. Беренче осталык дәресләрен







М.Х.Сәлимҗанов куйган спектакльләрдән күренешләр:
1. «Бирнәсез кыз», А.Н.Островский; 2. «Әни килде», Ш.Хөсәенов; 3. «Әлдермештән Әлмәндәр», Т.Миңнуллин.







Х.Й. С ә л и м җ а н о в : 1. Яго («Отелло», У. Шекспир); 2. Габбас Галин («Томан арты», Ш. Камал) рольләрендә.



Х.Й. Сәлимҗанов.



Р.И. Сәлимов.

Г.*Кариевтан* ала. Татар театр техникумын тәмамлаганнан соң (1926, 1 нче чыгарылыш), Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Искиткеч тышкы кыяфәте, ачык темпераменты, күзәтүчәнлеге С.ка Сөнгать («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин), Искәндәр, Габбас Галин («Ут», «Томан арты», Ш.Камал), Хәлил, Исмәгыйль («Галиябану», М.Фәйзи), Хафиз («Шәмсекамәр», М.Әблиев), Мирзахан («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Алчын, Чичән, Марат, Айдар («Хуҗа Насретдин», «Җирән Чичән белән Карачәч сылу», «Рәйхан», «Зифа», Н.Исәнбәт) һ.б. күп кенә үзенчәлекле, кызыклы образлар тудырырга ярдәм итә. 1938 дә Н.А.Островскийның «Корыч ничек чыныкты» романы буенча куелган спектакльдә Павка Корчагин ролен зур уңыш б-н башкара; ш.у. Хлестаков («Ревизор», Н.В.Гоголь), Яго («Отелло», У.Шекспир) образларын гәүдәләндерә. Режиссёр буларак, Татар акад. театры сәхнәсендә — Һ.Такташның «Камил», Ә.Рахманколыйның «Шомлы шәүләләр», Ш.Камалның «Таулар», Т.Гыйззәтнең «Чаткылар», Ф.Бурнашның «Лачыннар», М.Фәйзинең «Галиябану» әсәрләре буенча спектакльләр; ш.у. Әлмәт татар драма театрында да берничә спектакль куя; Казан радиосында Г.Әпсәләмовның «Газинур», М.Фәйзинең «Галиябану», Ә.Фәйзинең «Тукай», Ш.Камалның «Козгыннар оясында», Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар», «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрләре буенча радиоспектакльләр эшли. Нәфис сүз остасы буларак, С. концертларда һәм радиода шигырьләр укып чыгышлар ясый. С. ш.у. пьесаларны татарчага тәрҗемә итү, татар прозаикларының әсәрләрен сәхнәләштерү б-н дә шөгыльләнә.

Ә с ә р.: Нәфис сүз. К., 1959; Артист язмалары. К., 1966.

*Әд.:* И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; Народные артисты. К., 1980; И л я л о в а И.И. Театр имени Камала. К., 1986.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**СӘЛИ́МОВ** Венер Асылгәрәй улы (1.5.1941, Минзәлә ш.), генерал-майор (1993), ТРның атказ. юристы (2001). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1964). 1966–67 елларда ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы. 1967 дән ТАССР Дәүләт куркынычсызлыгы органнарында, 1982–93 тә ТР Дәүләт куркынычсызлыгы ком-ты рәисе урынбасары, 1993–99 да рәисе. 1999–2010 да ТР Иминлек советы секретаре. Кызыл Йолдыз, Почёт орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**СӘЛИ́МОВ** Равил Исмәгыйль улы (12.4.1949, Бөгелмә ш.), актёр, ТССРның халык артисты (1991). 1968 елдан рәссам-башкаручы, Бөгелмә рус драма театрында ярдәмче состав актёры, 1970 тә төп актёрлар составына күчерелә. 1975–76 да Рыбинск шәһәрендәге драма театры актёры. 1977 дән кабат Бөгелмә театрында. Һәр ролenә сәнгатьчә чаралар табуда бертуктаусыз эзләнү С.ка шактый гына күренекле образлар иҗат итәргә мөмкинлек тудыра: трагик Мирзанур («Ай булмаса, йолдыз бар», Т.Миңнуллин), Эйнштейн («Физиклар», Ф.Дюрренматт); лирик Абдулла («Әбиләргә ни җитми?», Ф.Бүләков; К.Тинчурин исем. IV Респ-ка фестивалендә иң яхшы ир-ат роле өчен приз), Аттилио, Доменико Сориано («Цилиндр», «Филумена Мартурано», Э. де Филиппо); комик Скапен («Скапен хәйләләре», Ж.Б.Мольер)



Р.И. С ә л и м о в Барон ролендә («Бөкре кеше», С.Мрожек; уңда – Онек ролендә А.Л. Кочетов).

һәм сатирик Подсекальников («Үз-үзенә кул салучы», Н.Р.Эрдман) образлары шундыйлардан. Ул башкарган Тимофей («Култык таяклары белән узган исем бәйрәме», С.Л.Лобозёров), Шиндин («Без, түбәндә кул куючылар», А.И.Гельман), Игорь («Раштуа көнендәге татлы хыяллар», Н.М.Птушкина) рольләре тормышчан хак, эчке инандыру көченә ия булулары б-н аерылып тора.

*И.И.Илялова.*

**СӘЛИ́МОВ** Расих Бәхтигәрәй улы (18.8.1931, Минзәлә р-ны Чулпан а.), математик һәм механик, физика-матем. фән. д-ры (1973), проф. (1973), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1986). 1954 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан авиация ин-тында (1957–63), Казан югары артиллерия инженер-командирлары уч-щесендә (1963–71) эшли. 1971 дән Казан архит-ра-төзелеш ун-тында югары матем. каф. мөдире. Хезмәтләре аэрогидромеханиканың кайтма кырый мәсьәләләренә карый. С. тизлекнең хордалы диаграмма рәвешендә бирелгән бүленеше буенча канат профилен төзү алымнарын эшли. Башлангыч өлкәләренә якын булган кайтма һәм катнаш кайтма кырый мәсьәләләрне чишү һәм аларның аэрогидромеханикада һәм фильтрлау теориясендә кулланышларын таба. Аналитик функцияләр өчен Гильберт кырый мәсьәләләрен чишү алымнарын тәкъдим итә. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009).

Х е з м.: Некоторые основные задачи об изменении контуров теории аналитических функций и их приложения к механике жидкости. К., 1970; К вопросу о поведении производной функции, реализующей конформное отображение вблизи угловой точки границы области // Изв. вузов. Математика. 1977. № 2; Новый подход к решению краевой задачи Гильберта для аналитической функции в многосвязной области // Изв. вузов. Математика. 2000. № 32.

**СӘЛИ́МОВ** Фәрит Ибраһим улы (18.9.1948, Казан), математик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009), физика-матем. фән. канд. (1983). 1971 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында (1971–73), 1974 тән теоретик кибернетика кафедрасында. Хезмәтләре дискрет математикага, тулылык, катлаулылык теорияләренә, автоматлар теориясенә, сөйләм теле синтезына карый.

С. бүленешләр алгебрасында тулылык мәсьәләләрен, идарә системаларының кайбер классларында ихтималый үзгәрткечләр куллануның катлаулылыгын тикшерә. Персональ компьютерларны төрле операцион системалар өчен татарча локальләштерүгә караган программа пакетлары; ТРдагы паспорт өстәлләре һәм загслар өчен ике телдә информация-программа комплекслары эшли. Татар сөйләм теле синтезаторын, Казан ун-тының 1960–90 еллар диалектологик экспедицияләре материаллары буенча рус сөйләшләренең электрон китапханәсен төзү эшләрен башкара. Дәүләт бүләге ТР мәгариф системасында татар теленең дәүләт теле буларак кулланылышын фәнни, укыту-методик һәм информация-программалар ягыннан тәэмин итүгә караган хезмәте өчен бирелә.

Х е з м.: Конечная порожденность некоторых алгебр над случайными величинами // Вопр. кибернетики. 1982. Вып. 86; О максимальных подалгебрах алгебр распределений // Изв. вузов. Математика. 1985. № 7; Задача о минимальном имплицирующем векторе // Мат. вопр. кибернетики. 1991. Вып. 3 (автордаш).

**СӘЛИ́МОВ** Хәйдәр (1884, хәзерге Ульянов өлкәсенең Мукшы Күле а. — ?), шагыйрь. Башлангыч белемне туган авылында ала, соңрак Самара шәһәренең татар мәктәбендә укый. 1906–07 елларда укыта. 1917 дән соң Самара губернасы авылларында коммуналар оештыру б-н шөгыльләнә, балалар укыта. 1913–15 тә «Ак юл» ж-лында беренче шигырьләре басыла, 1917 дән соң «Яңа көч» г-тасында фельетоннарын һәм сатирик шигырьләрен бастыра.

*Әд.:* Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. 1 кит.

**СӘЛИ́МОВ** Хәлил Хәлим улы (30.9.1947, Апас р-ны Дәвеш а. — 14.7.2006, шунда ук), тел галиме, филол. фән. д-ры (1999), проф. (2000), ТССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1990). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1971), шунда ук эксперименталь фонетика лаб-ясендә эшли, 1976 елдан — татар теле кафедрасында. 1981 дән Алабуга пед. ун-тында (1986–90 да татар филологиясе каф. мөдире). Хезмәтләре татар авазларына спектраль анализ бирүгә, татар теленең фонетик һәм просодик системаларына, татар графикасы һәм орфографиясенә карый. С. — үзешчән композитор, бөтенсоюз һәм бөтенроссия халык иҗаты смотрлары лауреаты.

Х е з м.: Тел гыйлеме терминнары сүзлеге. К., 2005; Орфоэпический словарь татарского языка. Наб. Челны, 1995; Орфография татарского языка на основе латинской графики. К., 2000; Сопоставительная фонетика татарского и русского языков. Елабуга, 2007 (автордаш).

**СӘЛИ́МОВА** Дания Әбүзәр кызы (2.1.1957, Азнакай р-ны Әлки а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (2001), проф. (2003). Казан ун-тының татар филологиясе (1981) һәм милли мәктәптә рус теле һәм әдәбияты (1991) белгечлекләре буенча филол. ф-тын тәмамлый. 1982 елдан Алабуга пед. ун-тында (1998 дән рус һәм контрастив тел белеме каф. мөдире). Хезмәтләре хәзерге татар теле морфонологиясенә, рус һәм татар телләренең чагыштырма фонетикасы, сүз ясалышы һәм морфологиясенә, тәрҗемә теориясенә карый. Югары уку йортлары һәм урта мәктәпләр өчен дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре авторы. РФнең мактаулы югары белем мәктәбе хезмәткәре.

Х е з м.: Русский глагол. Наб. Челны, 1994; Система частей речи русского и татарского языков. К., 2001; Части речи: история изучения и вопросы классификации. К., 2004; Морфемика и словообразование. К., 2012 (автордаш); Двуязычие и перевод: теория и опыт исследования. М., 2012 (автордаш).

**СӘЛИ́МОВА** Хәдичә Нур (Нури) кызы (11.9.1907, Пермь губ., Пермь өязе Лысьва а. — 18.8.1980, Минзәлә ш.), драма актрисасы, ТАССР һәм РСФСРның атказ. артисты (1950, 1957). 1925 елда — Казан татар пед. техникумын, 1930 да Казан берләшкән театр-сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлый; Татар акад. театры труппасына кабул ителә, анда зур булмаган рольләр башкара. 1935 тән Минзәлә татар драма театры актрисасы, аның сәхнәсендә зур тәҗрибә туплый, үзенчәлекле осталыгы формалаша. С. тудырган образлар рухы б-н халыкчан традицияләргә һәм карашларга якын була, тамашачыда зур кызыксыну уята. Аеруча истә калырлык, игътибар үзәгендә булган рольләре — Бәдига, Галимәбану («Галиябану», М.Фәйзи), Хәдичә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Гөлҗиһан («Банкрот», Г.Камал), Майлыбикә, Назлыбикә, Хәерниса, Фәрдәнә («Язылмаган законнар», «Тамырлар», «Сатучылар», Ю.Әминев), имче карчык Павка («Кара бүре», Н.Арбан), Ковшик («Балан куаклыгы», А.Е.Корнейчук), Васса («Васса Железнова», М.Горький), Огудалова, Кручинина («Бирнәсез кыз», «Гаепсездән гаепләләр», А.Н.Островский).


Х.Н.Сәлимова.

*Әд.:* Г ы й м р а н о в а Д.Э. Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры. К., 2007.

*Д.Э.Гыймранова.*

**СӘЛИМУ́ЛЛИН** Линар Сәлимулла улы (13.1932, Кама Тамагы р-ны Кече Карамалы а. — 1993, Киев), спортчы, тренер (ирекле көрәш, самбо), СССРның спорт остасы (1954, самбо буенча), 1956, ирекле көрәш буенча), Украинаның атказ. тренеры (1971), бөтенсоюз категорияле судья (1970). Киев физик культура ин-тын тәмамлый (1962). Спорт б-н 1948 елдан «Динамо» физик культура-спорт җәмгыятендә шөгыльләнә башлый (Казан, тренеры — Н.И.*Моряшичев*). 1957–62 дә СССРның җыелма командасы әгъзасы. СССР 1954 (самбо), 1955 (ирекле көрәш) чемпионы; СССР чемпионатында бронза медаль ала (1958), дөнья Кубогы этабында көмеш медаль ала (1956); Олимпия уеннарында катнаша (1956, ирекле көрәш). 1955 тән Киевта «Динамо» физик культура-спорт җәмгыятендә тренер булып эшли, СССРның 20 ләп спорт остасын әзерли. Талса шәһәренең мактаулы гражданы (АКШ).

**СӘЛКИ́** (9 йөз уртасы — 10 йөз башы), Болгар идарәчесе. Болгар кабиләләрен берләштерү сәясәтен үткәрә. Ислам кабул иткән һәм Абдаллаһ исемен алган дип фараз ителә.

**СӘМӘКӘ́Й** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 33 *км* көнчыгыштарак, Ургыды елгасы буенда. 2010 елда 338 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1735 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Семякова, Семенклеева исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә. 20 йөз башында С.дә мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1808,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Нөркәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 110 кеше, 1816 да — 117 ир-ат; 1834 тә — 373, 1859 да — 306, 1870 тә — 799, 1897 дә — 1133, 1920 дә — 1462, 1926 да — 1182, 1938 дә — 833, 1949 да — 557, 1958 дә — 504, 1970 тә — 558, 1979 да — 396, 1989 да — 300, 2002 дә — 320 кеше.

**СӘМӘНДӘ́Р** (Самандар), Төньяк Кавказда Хәзәр каганлыгындагы урта гасырлар шәһәре. Чыганакларда 8 йөздән, еш кына гарәп-хәзәр сугышлары б-н бәйле рәвештә искә алына. Шәрекъ галимнәре әл-Истәхри һәм ибне Хәүкәл (10 йөз) хезмәтләрендә Хәзәр иленең мөселманнар күпләп яшәгән һәм мәчетләре булган зур шәһәре дип телгә алына. Шәһәр яшеллек һәм йөзем бакчаларының күплеге б-н дан тота. 720–30 елларда С. — Хәзәр каганлыгының башкаласы. 968–69 да Киев кенәзе Святослав гаскәре тарафыннан яулап алына һәм җимерелә.

*Әд.:* А р т а м о н о в М.И. История хазар. Л., 1962; Н о в о с е л ь ц е в А.П. Хазарское государство и его роль в истории Восточной Европы и Кавказа. М., 1990; П л е т н ё в а С.А. Очерки хазарской археологии. М., 2000.

*И.Л.Измайлов.*

**СӘМӘРКА́НД** посёлогы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 35 *км* көньяк-көнбатыштарак, Вятка елгасының югары агымы (Чишмәнең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 1 кеше яши. 1925 тә Кичүчат авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оештырылган көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Әлмәт волостенда. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 92, 1938 дә — 121, 1949 да — 121, 1958 дә — 64, 1970 тә — 39, 1979 да — 36, 1989 да — 7 кеше; 2002 дә даими яшәүчеләр юк.

**СӘМИГУ́ЛЛИН** Әдһәм Зиннәт улы (1.10.1935, Әтнә р-ны Җилгелде а. — 11.8.2001, шунда ук), галим агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1985). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1971). 1951–98 елларда Әтнә р-нында эшли: Күәм МТСнда йөк ташучы, Дусым авылы клубы мөдире (1952 дән), К.Маркс исем. к-зда сарык фермасы мөдире (Дусым, 1954 тән), Күәм авылы советы рәисе (1959 дан), «Игенче» к-зында бригадир (1959 дан), рәис урынбасары (1967 дән), рәис (Күәм а., 1968 дән), район башкарма ком-тының азык-төлек һәм а.х. идарәсе башлыгы (1994–98). С. җитәкче булганда, «Игенче» к-зында бөртекле ашлык җитештерү 2,7 тапкыр, бәрәңге — 2,2, сөт — 2,5, ит — 1,6 тапкыр, бөртек ашлык һәм бөртекле-кузаклы культуралар — 1 *га* дан 8,21 *ц* дан 36,33 *ц* га, бәрәңге 80,5 *ц* дан 187,7 *ц* га арта. Хуҗалык җитештерүендәге югары күрсәткечләре өчен «Югары культуралы игенчелек колхозы» (1971), «Югары культуралы терлекчелек колхозы» (1984) дигән мактаулы исемнәргә лаек була. КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКларының Мактау грамотасы (1975, 1980), РСФСР МСның күчмә Кызыл Байрагы (1977) б-н бүләкләнә. 1975–80 дә ТАССР ЮС депутаты. Бөтенроссия к-злар советы әгъзасы (1980–85). Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**СӘМИГУ́ЛЛИН** Галим (Егор Фёдоров) (? — 1867 дән соң), Казан губернасында 19 йөзнең 2 нче яртысында керәшен татарларны мөселманлыкка кайтару хәрәкәтен оештыручыларның берсе; Казан губернасының Чистай өязе Югары Никиткино авылы керәшен татары. 1856 елда үзенең авылы, Чистай һәм Спас өязләре авыллары керәшен татарларның гозерен үтәү йөзеннән ирекле рәвештә ислам динен тотарга рөхсәт итүләрен үтенгән гозер кәгазен яза һәм шул үтенеч б-н С.-Петербургка бара. 1865 тә керәшен татарларны борынгы бабайлар диненә кайтырга үгетләүдә актив катнаша, кабат алар өчен, ислам динен тотырга рөхсәт сорап, гозер кәгазьләре яза. 1867 дә Казанда кулга алына. Турухан краена (Себер) сөргенгә җибәрелә.

*Әд.:* З а г и д у л л и н И.К. К вопросу отпадения крещёных татар Казанской губернии в мусульманство 1866 года // Национальный вопрос в Татарии дооктябрьского периода. К., 1990.

*И.К.Заһидуллин.*

**СӘМИГУ́ЛЛИН** Камил Искәндәр улы (22.3.1985, Мари АССРның Звенигово р-ны Красногорский пос.), дин эшлеклесе. 2003 тә Төньяк Кавказ ислам ун-тында (Махачкала ш.), 2003–07 дә «Исмаил ага» мәчете каршындагы мәдрәсәдә (Төркия, Истанбул), 2008–13 тә Казан ислам ун-тында белем ала. 2007–08 дә Түбән өлкәсенең шәһәр тибындагы Новоаганск посёлогындагы мәчеттә, 2008 дән Казандагы «Тынычлык» мәчетендә имам. 2011 дән ТР Мөселманнар Диния нәзарәтенең нәшрият бүлеге мөдире, 2012 дән мөфтинең фәнни эшләр буенча урынбасары, 2013 тән Нәзарәтнең рәисе, мөфти.

**СӘМИГУ́ЛЛИН** Рәдис Нигъмәтҗан улы (16.4.1939, БАССРның Борай р-ны Зур Бадрак а.), вет. паразитологы, вет. фән. д-ры (1991), проф. (2000), БРның атказ. а.х. хезмәткәре (2008). Башкорт а.х. ин-тын (Уфа ш.) тәмамлаганнан соң (1967), Удмурт АССРның Грахово р-ны «Новогорский» с-зында вет. табибе булып эшли. 1970–94 елларда (бүленеп) Башкортстан фәнни-җитештерү вет. лаб-ясендә: вет. табибе, фәнни хезмәткәр, паразитология бүлеге мөдире (1977–84, 1993–94). 1984–93 тә Башкортстан терлекчелек һәм терлек азыгы җитештерү фәнни-тикшеренү һәм проектлау-технол. ин-тында: баш фәнни хезмәткәр, сарыкчылык секторы җитәкчесе. 1994 тән Башкортстан агросәнәгать комплексы (АСК) кадрларын яңадан әзерләү һәм белем күтәрү ин-тында, АСКның прогрессив технологияләре каф. профессоры (1998). Фәнни тикшеренүләре ашказаны-эчәк тракты гельминтозы очракларында дәвалау-профилактика гамәлләренең нәтиҗәлелеген күтәрү буенча комплекслы чаралар эшләүгә, терлек организмы өчен зарарсыз яңа дәвалау-профилактика чаралары — антигельминтиклар эзләү мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Профилактика нематодозов овец // Ветеринария. 1983. № 9; Феносмолин для дезинвазии животноводческих объектов // Ветеринария. 1989. № 12; Микроклимат помещений при различных способах содержания овец // Ветеринария. 1999. № 9.

**СӘМИ́ТОВ** Илдус Мөнир улы (24.3.1954, Казан), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), Казан казна дары з-дында эшли: инженер, мастер, участок башлыгы, бүлек башлыгы урынбасары, цех башлыгы урынбасары, баш технолог (1991 дән), җитештерү башлыгы урынбасары (1998 дән), баш инженер (2001 дән), ген. директор урынбасары (2003 тән). Дәүләт бүләге көндәшлеккә сәләтле продукция эшләүнең диверсификацияле технологияләрен булдыруда катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 3 патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә. «2 нче дәрәҗә Россия корал төзүчеләре берлеге», Россия Эчке эшләр министрлыгының 2 нче дәрәҗә «Хезмәттәге казанышлары өчен» күкрәк билгеләренә лаек була.

Х е з м.: Концепция и стратегия развития современного порохового производства. К., 2009 (автордаш).

**СӘМИ́ТОВ** Йосыф Юныс улы (5.4.1925, Вятка ш. — 17.1.1987, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1967), проф. (1971), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1985). 1951 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, органик кушылмалар структурасын өйрәнү лаб-ясе мөдире (1957–85), бер үк вакытта, 1965–70 тә, СССР ФА Казан ф-лының Органик һәм физик химия ин-тында эшли. 1957–58 дә Ханой политехник ин-тының физика кафедрасында стажировка үтә (Вьетнам Демократик Респ-касы). Хезмәтләре югары дәрәҗәдә ачыклаучы ТМР спектроскопиясенә карый. С., СССРда беренчеләрдән булып, ТМР күренешен органик химия тикшеренүләрендә куллана. Югары дәрәҗәдә ачыклаучы ТМР спектрометр, спектроструктур корреляцияләр нигезендә молекулаларның фәзаи төзелешен өйрәнү өчен теоретик һәм эксперименталь нигезләмәләр эшли. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009, вафатыннан соң). Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, Вьетнам Демократик Респ-касының 3 нче дәрәҗә Хезмәт ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Влияние растворителя на барьер инверсии диперекиси ацетона // Журн. структурной химии. 1970. Т. 11, № 4 (автордаш); Атлас спектров ЯМР пространственных изомеров: В 2 т. К., 1978–83; Стереоспецифичность констант ядерного спин-спинового взаимодействия и конформационный анализ. К., 1990.

**СӘМИ́ТОВА** Газизә Баһаветдин кызы (15.12.1862, Әстерхан губ. Ташлыяр а. — 1929, шунда ук), шагыйрә. Чыгышлары Казан губернасының Тәтеш волостеннан булган сәүдәгәрләр гаиләсеннән. Гомеренең күп өлешен туган авылында яши. Үзлегеннән рус, калмык һәм гарәп телләрен өйрәнә; татар фольклоры әсәрләрен җыя. Фәлсәфи һәм социаль тематикалы лирик шигырьләре формасы б-н халык җырларын, бәет һәм мөнәҗәтләрне хәтерләтә. Аларның күбесе С.ның биографиясе б-н бәйле, эчкерсезлеге б-н җәлеп итәләр, тормыш мәгънәсе, хатын-кызның авыр язмышы хакында уйланулар б-н кызыклы. Әсәрләренең кульъязмалары РФА Шәрекъ ин-тының Петербург бүлеге китапханәсендә саклана.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1965.

*Әд.:* Өмет йолдызлары: XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы татар хатын-кыз язучылары әсәрләре. К., 1988.

**СӘМИ́ТОВА** (Галкина-Сәмитова) Гөлнара Искәндәр кызы (9.7.1978, Чаллы ш.), спортчы (җиңел атлетика), ТРның, Россиянең атказ. спорт остасы (2004, 2008). 2004 елда Кама физик культура ин-тын тәмамлый (Чаллы ш.). Спорт б-н 1986 да Халык мәгарифе шәһәр идарәсенең Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә шөгыльләнә башлый (Чаллы ш.); тренерлары — В.И.Аржевитин, А.С.Тюлеманов (1992–97), М.Н.Чинкин (1998–2008), Г.М.Суворов (2008 дән). Россия (2003, кыш, каршылыклар б-н 2000 *м* га йөгерүдә, җәй, каршылыклар б-н 3000 *м* га йөгерүдә; 2004, кыш, 1500 *м* га йөгерүдә, җәй — 5000 *м*, 2007 — 08; каршылыклар б-н 3000 *м* га йөгерүдә; 2008, кросс 6 *км*); Мәскәү (2009, каршылыклар б-н 3000 *м* га йөгерүдә); бертуган Знаменскийлар мемориалы чемпионатларында (2007, каршылыклар б-н 3000 *м* га йөгерүдә); «Открытие сезона» (2007, 150 *м* га йөгерүдә, Мәскәү), «Золотая лига» (2007, каршылыклар б-н 3000 *м* га йөгерүдә, Осло), «Вызов России» (2009, 1500 *м* га йөгерүдә), Италия (2004) һәм Греция (2007, каршылыклар б-н 3000 *м* га йөгерүдә) халыкара ярышларында җиңүче. Олимпия уеннары (2008, каршылыклар б-н 3000 *м* га 8 *мин* 58,81 *с* нәтиҗәсе б-н йөгерүдә) чемпионы, рекордчысы; Европа кубогы иясе (2003–04, 2007, каршылыклар б-н 3000 *м* га йөгерүдә). Россия чемпионатында көмеш медаль (2007, 5000 *м* га йөгерүдә), дөнья чемпионатында (2004), халыкара турнирда (2007, каршылыклар б-н 3000 *м* га йөгерүдә, Хорватия) бронза медальләр ала; Олимпия уеннарында катнаша (2004). 2003 тән Россия җыелма командасы әгъзасы. 2008 дән ТР Эчке эшләр министрлыгы органнарында эшли. Дуслык, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары б-н бүләкләнә.

**СӘМРУ́Г КОШ**, төрки мифология һәм фольклор персонажы. Мифик Каф тавы артында яши торган гаҗәеп зур кош. Фарсы мифологиясе, фольклоры һәм әдәбиятыннан килә («Авеста» борынгы фарсы дини истәлегендә — Симург, Сенмурв). Күпчелек төрки халыклар фольклорында һәм әдәбиятында телгә алына. Алардагы С.к. — гаҗәеп куәтле кош; ул балаларын Аждаһадан коткарган каһарман егеткә рәхмәт укый, аңа ярдәм итә һәм аны яклый. С.к. төрле образларда күренә. Татар әкиятләрендә (мәс., «Камыр батыр») ул — кошлар патшасы. «Урал батыр» башкорт эпосында — күк патшасы һәм хуҗасы, Ай, Кояш исемле ике хатыны бар, шулардан кеше ыругы барлыкка килгән. Үзбәк фольклорында С.к. — кеше башлы гаҗәеп зур кош; казакъ фольклорында ике башлы кош: бер башы кеше кебек сөйләшә, икенчесе кош кебек сайрый. Кайбер сюжетларда (мәс., «Мәче һәм ярлы егет» татар әкияте) С.к. каһарман егеткә җеннәр һәм пәриләр өстеннән хакимлек бирүче тылсымлы балдак

бүләк итә. Кайвакыт С.к. каһарман егеткә каршы дошман көч, зирәк кош, язмыш коралы булып килеп баса («Шаһнамә», Фирдәүси).

*Әд.:* Хисаметдинова Ф.Е. Самрау // Башкорт мифологияһы. Өфө, 2002; Симург // Мифы народов мира. М., 1988. Т. 2; Рак И.В. Мифы древнего и раннесредневекового Ирана: Зороастрийская мифология. СПб., 1998.

**СӘНӘГА́ТЬ**, икътисад өлкәсе, илнең (төбәкнең) матди һәм социаль үсеш дәрәҗәсен билгели. Файдалы казылмалар чыгару, эшкәртү, машиналар һәм җиһазлар, химия, нефть продуктлары, азык-төлек, халык куллануы әйберләре һ.б. җитештерүне, электр энергиясе, газ һәм су алу-бүлдыру һәм бүлүне үз эченә ала.

ТРның хәзерге С. комплексы уңайлы геогр. һәм социаль факторлар җирлегендә оеша. Бу факторларның иң әһәмиятлеләре — төбәкнең сәүдә-транспорт юллары киселешендә урнашуы, бай табигать ресурслары, җирле халыкның күнекмәләре һәм традицияләре. *Таш гасырда* кешенең шәхси ихтыяҗларын тәэмин итү өчен барлыкка килеп, металл эшкәртү үзләштерелгәннән соң (б.э.к. 2 мең ел чамасы элек), С. һөнәр рәвешендә хуҗалыкның мөстәкыйль тармагына әверелә (к. *Бронза гасыр, Тимер гасыр*). Хезмәт бүленеше тирәнәю, сәүдә үсеше, шәһәрләр һәм *Идел буе Болгар дәүләте* оешу процессында һөнәрчелекнең яңа төрләре — металлургия, тимерчелек, корал ясау, бакыр һәм бронза кою, чүлмәкчелек, зәргәрчелек, сөяк һәм таш кисү, агач эшкәртү барлыкка килә һәм бүленеп чыга. *Алтын Урда* һәм *Казан ханлыгы* дәверләрендә болгар осталары традицияләре үсеш кичерә. Төбәк терр-ясе Рус дәүләтенә кушылгач, татарлар шәһәрләрдән куылып, *тыелган товарлар* турындагы фәрман чыгарылганнан соң, бу традицияләр бик озакка өзелә. Россиянең үзәк районнарыннан күчереп утыртылган кешеләр төбәк терр-ясенә яңа һөнәрләр, эшләнмәләр, техник күнекмәләр алып киләләр. 1565 елга, башлыча, җирле йомышлы халыкның ихтыяҗларын тәэмин иткән һөнәр белгечләренең саны 100 дән арта. Һөнәрчеләрнең яртысы чамасы азык-төлек, чирегеннән күбрәк өлеше өс һәм аяк киемнәре җитештерү, кайберләре агач эшкәртү б-н шөгыльләнә. Алар (500 дән артык кеше) Казанда яшәп эшлиләр, шунда ук күкерт һәм дары эшләп чыгаручы беренче казна пр-тиесе («яшел утар») барлыкка килә.

17 йөздә, гомумроссия базары оешуга бәйле рәвештә, җирле һөнәрләрнең товарлыклы асылы көчәя. Һөнәрчеләрнең саны ике тапкыр арта. Бәйле һәм яллы эшчеләр хезмәтеннән файдаланулы (11 кешегә кадәр) эре остаханәләр барлыкка килә. Аерым белгечлекләр буенча сан ягыннан беренчелекне итекчеләр, күнчеләр, тегүчеләр, тире иләүчеләр һәм баш киемнәре тегүчеләр, аннан соңгы урынны итчеләр, икмәк һәм күмәч пешерүчеләр, тегермәнчеләр һәм балыкчылар били, алардан соң балта осталары, мичкә ясаучылар, кирпеч сугучылар һәм ташчылар чиратлаша. Бу чорда татарларда шәһәр һөнәрчелеге традицияләре яңара; Казан эре һөнәрчелек үзәкләренең берсенә, төп күн һәм күн аяк киемнәре җитештерү урынына әверелә.

17 йөз ахырында — 19 йөз башында Россия һәм халыкара базарлар, ш.у. хәрби ихтыяҗ өчен күпләп бер типтагы продукция эшләп чыгарган тармакларда мануфактура (к. *Мануфактура*) тибындагы, казна карамагындагы һәм хосусый пр-тиеләр — *Казан адмиралтействосы, Казан постау мануфактурасы, Помпа каеш-күннәре заводы, Казан дары заводы, күн эшләнмәләре мануфактуралары, комач мануфактуралары*, тукыма, язу кәгазе чыгаручы, бау ишүче пр-тиеләр, *бакыр кою заводлары*, сабын кайнату пр-тиеләре (к. *Сабын җитештерү*) барлыкка килә. 1812 гә Казан губернасында 140 тан артык сәнәгать пр-тиесе исәпләнә, аларда 4,8 меңләп кеше эшли. Эшчеләрнең күпчелеге постау (2,3 мең кеше), күн (811), бакыр (760), киҗе-мамык тукымалар (534), сабын һәм шәмнәр (183), язу кәгазе (117 кеше) җитештерү тармакларына карый. Кайбер эре пр-тиеләрдә эшчеләр саны 1,6 мең кешегә җитә. Казна һәм алпавыт пр-тиеләрендә беркетелгән, посессион, крепостной крәстияннәр, ш.у. рекрутлар эшли; сәүдәгәрләр, мещаннар һәм крәстияннәр милкендәге пр-тиеләрдә, башлыча, ирекле яллы хезмәт файдаланыла. Пр-тиеләрнең якынча 35% ы татарлар кулында була, аларда барлык эшчеләрнең 31% ы туплана (к. *Буржуазия*).

19 йөз уртасына феодаль мөнәсәбәтләрнең саклануы, илнең башка өлкәләрендәге җитештерүне оештыруда алдынгырак ысуллар һәм технологияләр кулланган пр-тиеләр б-н көндәшлек, чимал базасының, транспорт коммуникацияләренең һәм сәүдә конъюнктурасының үзгәрүе төбәк С.енең традицион тармакларында кризиска китерә. С.нең алга таба үсеше капиталистик мөнәсәбәтләрнең (к. *Капитализм*) ныгып урнашуы һәм 1830 елларда текстиль, он җитештерүдә башланган сәнәгый борылыш б-н бәйле. 19 йөзнең 2 нче яртысында, бигрәк тә 1860–70 еллардагы буржуаз реформалардан соң, С.нең барлык тармакларында диярлек катлаулы механизмнар, пар һәм нефть двигательләре (1893 кә губернада 500 дән артык берәмлек урнаштырыла) б-н җиһазландырылган фабрикалар һәм заводлар барлыкка килә башлый; 1870–90 елларда С. пр-тиеләрен *электрлаштыру* башлана. Техник модернизация эре пр-тиеләрдә сәнәгый капитал туплану һәм Бельгия (*«Газ һәм электр»*), Франция, АКШ, Швейцариядән һ.б. илләрдән актив рәвештә эшмәкәрләр үтеп керү б-н бергә бара. С.нең яңа формалары б-н бергә һөнәрләр, вак кәсепләр дә саклана һәм үсеш кичерә.

1900 дә губернада 230 дан артык эре һәм уртача зурлыктагы С. пр-тиеләре исәпләнә, аларда 13,9 мең кеше эшли һәм 16,4 млн. сумлык продукция җитештерелә. *Химия сәнәгате* С.нең әйдәп баручы тармакларыннан берсе була (2,4 меңнән артык кеше һәм елга 7 млн. сумлык продукция). *Азык-төлек җитештерү сәнәгатендә* 2,6 меңнән артык кеше эшли, җитештерү күләме 4,5 млн. сум тәшкил итә (ашлык эшкәртү (к. *Ашлык хәзерләү һәм эшкәртү*) өлешенә тармакта эшләүчеләрнең 44% ы һәм продукциянең 47% ы, шәраб, аракы һәм сыра-бал кайнату пр-тиеләре өлешенә тиңдәшле рәвештә 43% һәм 39% туры килә). *Җиңел сәнәгать* тармагында 2,9 млн. сумлык эшләнмәләр җитештерелә, 5,7 мең кеше эшли, шактый өлешне өйдә эшләүчеләр тәшкил итә (текстиль пр-тиеләренең өлеше 67%, тармак эшләнмәләренең 67% ы, киез итек-киез, күн, тире иләү пр-тиеләренең өлеше тиңдәшле рәвештә 33% һәм 25%). Агач эшкәртү (1,1 мең эшче һәм 953 мең сумлык продукция) һәм металл эшкәртү (1,5 мең эшче һәм 553,7 мең сумлык продукция), *төзелеш материаллары сәнәгате* (312 кеше һәм 174,4 мең сумлык продукция) алга китә. Губернада гына түгел, илдә дә иң эре, техник җиһазланышы һәм хезмәтне оештыру буенча алдынгы пр-тиеләр исәбенә *Шәм-стеарин, сабын кайнату, глицерин җитештерү химия заводы* (2,3 мең кеше; елга 6,7 млн. сум) һәм *Алафузовларның завод-фабрикалар һәм җитештерү-сәүдә ширкәте* җитен эрләү-туку пр-тиесе (3 меңгә якын кеше; 1,5 млн. сум) керә. 20 йөз башында Казан губернасы Россия күләмендә химик матдәләр алу буенча 1 нче, сабын җитештерү буенча 4 нче, күн эшләү буенча 6 нчы урыннарны били. Пр-тиеләрнең күпчелек өлеше Казанда туплана (мәшгуль халыкның 85% ы һәм тулай продукциянең 81% ы). Пр-тиеләр саны буенча Чистай шәһәре икенче урында була. Аерым пр-тиеләр Тәтеш һәм Мамадыш шәһәрләрендә, Лаеш, Царёвококшайск, Мамадыш, Зөя, Спас, Чабаксар һәм Ядрин өязләрендә урнаша. Вак С. (тимерчелекләр, җил һәм су тегермәннәре, ярма яргычлар һ.б.) 4720 пр-тиене һәм оешманы колачлый, аларда 13,4 мең кеше эшли, җитештерүнең гомуми суммасы 474,8 мең сум тәшкил итә (1900). 50 меңгә якын кеше җир эшкәртү б-н бәйле булмаган һөнәрләр һәм кәсепләр (урман эшләре, мичкә ясау, читек тегү, комач, тире-яры, поташ җитештерү һ.б.) б-н шөгыльләнә. Үсеш кичерүгә карамастан, губерна, башлыча, аграр төбәк булып кала; 1913 тә җан башына сәнәгый җитештерү Россиядәге уртача күрсәткечтән 3,5 тапкыр кимрәк була. С.нең күп кенә тармаклары сезонлы эшли, кул хезмәте өстенлек итә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында С. күбесенчә хәрби продукция чыгарган пр-тиеләр (химия (шартлаткыч матдәләр), тегү һәм күн эшләү (өс һәм аяк киемнәре, амуниция) завод-фабрикалары) хисабына үсә. 1917 дә аларда С.тә мәшгуль 43,5 мең кешедән 20,4 мең кеше, ш.и. дары з-дында 9 мең кеше, хәрби киемнәр теккән «Победа» ф-касында 5–8 мең кеше эшли. Шул ук вакытта азык-төлек җитештерү, агач эшкәртү, сабын кайнату, полиграфия, төзелеш материаллары эшләү пр-тиеләрендә җитештерү кискен кими (аларның күбесе ябыла).

Окт. рев-циясеннән соң заводларда һәм фабрикаларда җитештерүгә һәм продукцияне бүлүгә эшчеләр контроле кертелә, 1918–21 дә пр-тиеләрне этаплап *национализацияләү* уздырыла. Бер үк вакытта С. б-н идарә итүнең вертикаль һәм терр. органнары булдырыла, товар-акча мөнәсәбәтләре бетерелә (к. *Хәрби коммунизм*), җиһазларны, чималны һәм кадрларны ябылучы вак һәм уртача зурлыктагы пр-тиеләрдән эреләренә кү-

черү юлы б-н җитештерү куәтләрен туплау гамәлгә ашырыла. 1917–18 дә Петроград губернасыннан Казан губернасына эре суднолар төзү (к. *Суднолар төзү*) һәм корыч кою пр-тиеләре эвакуацияләнә. Гражданнар сугышы чорында, илнең күп кенә терр-яләрендә контроль югалу шартларында, губерна Кызыл Армияне корал, сугыш кирәк-яраклары (хәрби корабльләр, артиллерия снарядлары өчен гильзалар, дары, туплар, пулемётлар, кием-салым, сабын, хәрби олаулар, чаңгылар һ.б.) б-н тәэмин итүче төп базаларның берсенә әверелә. Чимал, ягулык, квалификацияле кадрлар кытлыгы, завод-фабрикаларның әйләнештә акчалары булмау, җиһазларның тузуы 1918 дә 60 ка якын эре һәм уртача зурлыктагы пр-тиенең туктап калуына, эшчеләр санының 11 мең кешегә кимүенә китерә. 1920 дә башланган демобилизация С. җитештерүенең алга таба кыскаруына этәргеч бирә; 1922 гә 83 эре пр-тие яраксыз хәлгә килә. 1914–21 дә гомуми сәнәгый продукция җитештерү 4 тапкырдан да күбрәк өлешкә, ш.и. сабын эшләп чыгару — 20, аяк киемнәре — 5 тапкыр, җитен тукымалар җитештерү — 71% ка, күн эшләнмәләр чыгару 87% ка кими; С. эшчеләр саны (Казан буенча) 48% ка кими.

*Яңа икътисади сәясәткә* туры китереп, 1921–22 дә ТАССР ХХСның 252 эре, уртача зурлыктагы һәм аеруча мөһим вак пр-тиеләре хуҗалык исәбендәге трестларга (Күн тресты, Электр тресты, Урман тресты, Азык-төлек тресты, Силикат тресты, Татарстан киез итекләре, Татарстан өс киемнәре, Текстиль тресты), кантон берләшмәләренә (Буа, Бөгелмә, Алабуга, Мамадыш, Чаллы, Спас, Чистай) һәм комб-тларга берләштерелә. Бондюг химия з-длары берләшмәсе һәм Казан дары з-ды турыдан-туры Бөтенсоюз ХХС идарәсенә күчерелә. 41 пр-тие дәүләт учреждениеләренә, кооперативларга һәм аерым затларга арендага бирелә. Капиталистик мөнәсәбәтләр элементлары яңара. 1922 нең ахырында дәүләт пр-тиеләрендә 7,1 мең кеше, ш.и. 2,36 мең — күн җитештерү, 1,6 мең — текстиль, 1,37 мең — тегүчелек, 1 мең — металл эшкәртү, 427 — химия, 361 — агач эшкәртү, 323 — полиграфия, 153 — азык-төлек җитештерү, 146 кеше электр С.ләрендә эшли. 2,5 меңнән артык һөнәрче-кустарь пр-тиеләр (аларның 80% ы — хосусый милектә) респ-када барлык С. продукциясенең 70% ын җитештерә. 1922–26 да 60 эре пр-тие торгызыла, эшчеләр саны 16,9 мең кешегә җитә. 1927 гә төп тармакларда җитештерү күләме 1913 тәге күрсәткечләрдән арта. Бер үк вакытта эре дәүләт С.енең чагыштырмача өлеше үсә. Шулай да 1926–27 дә С.кә Татарстан халык хуҗалыгы тулай продукциясенең 24,3%ы гына туры килә. Оештыру һәм техник мәсьәләләрдә артталык саклана. 10–15 ел дәвамында яңартылмаган төп җитештерү фондларының тузу дәрәҗәсе 40–50% ка җитә.

1920 еллар ахырыннан Татарстанда, бөтен Советлар Союзындагы кебек үк, бердәм директив дәүләт бишьеллык планнары нигезендә тизләтелгән *индустрияләштерү* сәясәте уздырыла. 1 нче бишьеллыкта (1929–32) капитал салулар, башлыча, традицион җирле тармакларга юнәлтелә. Илдә иң эреләрдән булган мех, киез итек-киез, фанера комб-тлары, илдәге бердәнбер кетгут з-ды һ.б. төзелә, ит, сөт, икмәк пешерү, кондитер әйберләре җитештерү С.ләре индустриаль нигезгә күчерелә. 2 нче һәм 3 нче бишьеллыкларда (1933–42) авыр индустрия планлаштырылганнан тизрәк үсеш ала; аңа барлык капитал салуларның 60% тан күбрәк өлеше, җиңел һәм азык-төлек җитештерү С.ләренә якынча 25%ы һәм 15%ы юнәлдерелә. Респ-када *авиация сәнәгате*, приборлар төзү, ясалма каучук, кинофототасмалар, ясалма күн һ.б.ны җитештерү булдырыла. С. потенциалының күпчелек өлеше Казан–Яшел Үзән сәнәгате төйнәлешендә туплана. Сугышка кадәрге бишьеллыклар чорында Татарстанның С. комплексына барлыгы 1,4 млрд. сум чамасы капитал салына (башлыча, гомумсоюз һәм респ-ка (РСФСР) бюджетларыннан). 60 ка якын эре, 500 дән артык уртача зурлыктагы һәм вак пр-тие төзелә, электр энергетикасына нигез салына (Казан җылылык-электр үзәкләре — ТЭЦ-1,2, 20 ләп район электр станцияләре), эшләүче фабрика һәм заводларның күбесе реконструкцияләнә. Нәтиҗәдә, респ-ка С.енең төп җитештерү фондлары 13 тапкыр, С. продукциясе эшләп чыгару 12 тапкыр (ш.и. машиналар төзү һәм металл эшкәртүдә — 71, җиңел С.тә — 14, азык-төлек җитештерү С.ендә 9 тапкыр) арта. Респ-ка халык хуҗалыгы тулай продукциясендә С. өлеше 86% ка (ш.и. эре С. — 77,6%), эшчеләр саны 115 мең кешегә җитә. Татарстан С.е үсешенең темплары гомумсоюз күрсәткечләреннән 1,5 тапкыр югарырак була. 1940 ка респ-ка пр-тиеләре илдә эшләп чыгарылган кино тасмаларының һәм мех эшләнмәләрнең 50% ын, киез һәм фетр аяк киемнәренең 30% ын, олеин к-тасының һәм ясалма каучук алуда кулланылучы катализаторның 100% ын җитештерәләр. Индустрияләштерү чорында С. б-н идарә итүнең директива-хакимият алымнарына нигезләнгән, хезмәтне мораль стимуллаштыруның төрле формалары (соц. ярыш, стахановчылар хәрәкәте һ.б.) һәм репрессив характердагы чаралар б-н чиратлашкан үзәкләштерелгән системасы (тармак халык комис-тлары җитәкчелегендә) оеша.

Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан Кызыл Армиянең аеруча мөһим сәнәгый-тыл базасына әверелә. 1941–42 дә респ-када илнең көнбатыш өлкәләреннән эвакуацияләнгән 70 тән артык (ш.и. 30 эре) завод һәм фабрика урнаштырыла һәм файдалануга тапшырыла, аларда 76 мең кеше эшли; пр-тиеләрнең күпчелеге мобилизация планы буенча хәрби заказларны үтәүгә күчерелә, фронтка китүчеләр урынына эшче кадрлар туплау һәм әзерләү системасы җайга салына. 1943–45 тә С.тә өзлексез алымнарны гамәлгә кертү, җитештерүне рационализацияләү нигезендә ТАССРда хәрби продукция эшләп чыгару арттырыла. Респ-каның С. пр-тиеләре фронтка 13 млрд. сумлык 600 дән артык төрдә корал һәм хәрби техника, сугыш кирәк-яраклары, формалы киемнәр, ш.и. Пе-2, Пе-8, По-2 (У-2) бомбардировщиклары, броньлы катерлар, десант баркаслары, станоклы пулемётлар, миналар, гранаталар, авиация бомбаларының корпусларын һәм шартлаткычларын, снарядлар, укчы, артиллерия һәм реактив кораллар өчен дары зарядлары, бинокльләр, авиация, артиллерия, танк һәм снайпер төзәгечләре, перископлар, аэрофотоаппаратлар, аэрофотография һәм рентген плёнкалары, навигация приборлары, медикаментлар, чаңгылар, кыска туннар, шинельләр, унтлар, комбинезоннар, шлемофоннар, парашютлар һәм асылма системалар, аяк киемнәре, формалы җиңел киемнәр, эчке киемнәр һ.б.ны җибәрәләр. 1940–45 тә респ-ка С.енең тулай җитештерүе 2,2 тапкыр, ш.и. машиналар төзүдә (С. эшләп чыгарган продукциянең 2/3 дән артык өлеше) 6,8 тапкыр арта. С.тә җитештерү чаралары эшләп чыгаруның чагыштырмача өлеше 48,8% тан 83,3% ка кадәр үсә. Эвакуацияләнгән куәтләр җирлегендә авиация двигательләре төзү, сәгатьләр, ит консервлары, мед. инструментлары, трикотаж һәм киҗе-мамык тукымалар җитештерү тармаклары барлыкка килә. Чистай, Алабуга һ.б. шәһәрләрдә урнашкан пр-тиеләрнең саны арта. Татарстан эре индустриаль төбәккә әверелә. Сугыш тәмамлаганнан соң, С. куәтләре ремилитаризацияләнә һәм өлешчә реэвакуацияләнә, әмма аларның төп өлеше респ-када кала.

Татарстанның алга таба индустриаль йөзе формалашу эре нефть чыганаклары ачылу, нефтьне сәнәгый чыгара башлау (1943) һәм куәтле нефть-газ чыгару комплексы оешу б-н билгеләнә. 4 нче бишьеллыкта (1946–50) нефть С.енә барлык капитал салуларның 55% ы юнәлтелә. Нефть чыгару гаять кызу темплар б-н үсә (1950 дә — 866,5 мең *т*, 1958 дә — 31,8 млн. *т*, 1975 тә — 104,6 млн. *т*), нәтиҗәдә, Татарстан илдә иң эре нефть чыгаручы төбәккә әверелә (нефтьнең гомуми күләменең 30% ы). Нефть-газ чыгару ихтыяҗлары *нефть-газ машиналары төзү сәнәгате* барлыкка килүгә этәрә. Төзелеш материаллары С.е, бигрәк тә бетон һәм тимер-бетон эшләнмәләр җитештерү куәтләре күпкә үсә (1945–58 дә — 38 тапкыр); Урыссу һәм Зәй (Идел буенда иң эресе) ГРЭСлары төзелә. Нефть промыселлары тирәсендә шәһәр тибындагы посёлоклар челтәре үсеп чыга, азык-төлек җитештерү С.е, куллану әйберләрен эшләп чыгаручы башка тармаклар пр-тиеләре барлыкка килә, Татарстанның көньяк-көнчыгышында яңа эре *Әлмәт-Бөгелмә сәнәгать төйнәлеше* оеша.

Сугыштан соңгы елларда, нефть индустриясе үсеше б-н бергә, респ-када сәнәгый җитештерүнең башка, ш.и. оборона тармаклары да, бигрәк тә машиналар төзү һәм металл эшкәртү С.ләре (элеккечә үк Казан тирәсендә туплана) үсә бара. Приборлар төзү С.е, аеруча радиоэлектроника һәм исәпләү техникасы эшләп чыгару, мед. инструментлары С.е интенсив үсеш кичерә, компрессорлар һәм вакуумлы җиһазлар җитештерү барлыкка килә. Киң күләмле капитал салулар нәтиҗәсендә ягулык С.е Татарстанның иң эре сәнәгый тармагына әверелә. 1960 ка анда респ-ка-

ның барлык сәнәгый-җитештерү фондларының 45,8% ы (ш.и. нефть чыгаруда 44,6%) туплана; машиналар төзү һәм металл эшкәртүгә — 19,9%, электр энергетикасы һәм химия С.ләренең һәркайсына 7,8%, азык-төлек җитештерү С.енә — 5,9%, төзелеш материаллары С.енә — 4,3%, җиңел С.ка — 3,8%, урман һәм агач эшкәртү С.енә 3,1% туры килә. С. пр-тиеләрендә 287,1 мең кеше (респ-ка халык хуҗалыгында мәшгуль халыкның 28% ы) эшли. 1940–60 елларда С. продукциясенең гомуми күләме 12 тапкыр, ш.и. машиналар төзү һәм металл эшкәртүдә — 57,6, төзелеш материаллары җитештерүдә — 17,2, электр энергетикасы С.ендә — 13, химия С.ендә — 4,5, җиңел С.тә — 3,2, урман һәм агач эшкәртүдә, азык-төлек җитештерүдә 2,5 тапкыр арта.

1957–63 тә респ-каның С. комплексы б-н Татарстан икътисади р-нының ХХС, 1963–64 тә Урта Идел ХХС профиль идарәләре тарафыннан җитәкчелек ителә. Идарә итүнең тармак принцибыннан терр. принципка күчү омтылышы илнең аерым төбәкләрендәге пр-тиеләр арасында яшәп килгән хуҗалык бәйләнешләренең бозылуына, фән һәм җитештерү арасындагы элемтәләрнең йомшаруына китерә.

1950 еллар ахырында — 1970 елларда респ-када нефть чыгару җирлегендә *нефть-газ эшкәртү сәнәгате* һәм *нефть химиясе сәнәгате* оештырыла; соңыннан нефть чыгару һәм нефть химиясе пр-тиеләре төзүдән бушаган төзелеш оешмалары һәм эре төзелеш индустриясе *автомобиль җитештерү сәнәгатен* оештыру җирлеген тәшкил итәләр. Илдә полимер чимал һәм автомобиль шиннары җитештерү буенча алдынгы технологияләргә ия иң эре нефть химиясе пр-тиеләре («*Түбәнкаманефтехим*», «*Түбәнкамашин*», «Казаноргсинтез») һәм йөк автомобильләре чыгаручы заводлар комплексы (к. *КАМАЗ*) төзелә. Энергияне күп куллanучы нефть химиясе һәм автомобиль җитештерү С.е ихтыяҗлары электр энергетикасының куәтләрен алга таба үстерүгә китерә (к. *Түбән Кама ГЭСы*). Яңа нефть химиясе, автомобильләр төзү, энергетика пр-тиеләре һ.б. *Түбән Кама территориаль-җитештерү комплексының* үзәген хасил итәләр. 1970 елларның 2 нче яртысында нефть химиясе һәм автомобильләр төзүнең куәтләрен арттыру б-н бер үк вакытта чимал (нефть һәм урман) тармакларында җитештерү күләме кими бара, бу табигый запасларның азаюы б-н бәйле була һәм респ-каның көньяк-көнчыгышында хезмәт ресурсларының бушануына, социаль вазгыятьнең начараюына китерә. Әлеге үзгәрешләр нәтиҗәсендә гомуми кысаларда С. комплексының хәзерге структурасы оеша. 1985 тә С.нең төп фондларының гомуми күләмендә һәм керемендә әйдәүче тармакларның чагыштырмача өлеше (%): машиналар төзү һәм металл эшкәртү — 36,4 һәм 39,5, ягулык — 26,1 һәм 19,7, химия һәм нефть химиясе — 20,0 һәм 23,2, электр энергетикасы 9,0 һәм 8,2, төзелеш материаллары җитештерү — 2,8 һәм 1,6, азык-төлек җитештерү — 2,3 һәм 4,7, җиңел С. — 1,1 һәм 5,7, урман, агач эшкәртү һәм целлюлоза-кәгазь С.е — 0,8 һәм 0,6. 1960–85 тә С. продукциясенең күләме 6 тапкыр, ш.и. машиналар төзү һәм металл эшкәртүдә — 20,6, химия һәм нефть химиясендә — 18,3, электр энергетикасында — 12,2, төзелеш материаллары С.ендә — 5, азык-төлек җитештерүдә — 3, җиңел С.тә — 1,8, урман, агач эшкәртү һәм целлюлоза-кәгазь С.ендә — 1,5, ягулык С.ендә 1,4 тапкыр арта. Сәнәгый җитештерү персоналының саны 610,2 мең кешегә җитә (респ-ка халык хуҗалыгында мәшгуль халыкның 33,3% ы). ТАССР илнең индустриаль яктан иң алга киткән төбәкләренең берсенә әверелә.

Авыр индустриянең планлаштырылганнан тизрәк үсеше Татарстанның гомумсоюз ихтыяҗлары өчен җитештерү чаралары (җиһазлар, чимал һәм материаллар) эшләп чыгаруга йөз тоткан төбәккә әверелүенә китерә. Респ-кадан читкә С. продукциясенең 70% тан, ш.и. нефть, машиналар төзү һәм химия продукциясенең 90% тан артык, җиңел һәм азык-төлек җитештерү С.е эшләнмәләренең (авыр һәм җиңел С.ләрнең) 40% тан артыграк өлеше оборона максатларындагы продукция җитештерүдә файдаланыла. С.тәге структура үзгәрешләренә *фәнни-техник революция* зур йогынты ясый. 1965–85 тә респ-ка пр-тиеләрендә урнаштырылган механикалаштырылган өзлексез линияләрнең саны 656 дан 2769 га, автомат линияләрнеке 74 тән 695 кә, комплекслы-механикалаштырылган һәм автоматлаштырылган участокларның, цех һәм производстволарның саны 168 дән 1155 кә, комплекслы-механикалаштырылган һәм автоматлаштырылган пр-тиеләр 8 дән 54 кә кадәр арта. Сәнәгый хезмәтнең электр б-н тәэмин ителеше һәм җиһазландырылуы 2,9 тапкыр (ш.и. машиналар төзүдә һәм химия С.ендә — тиңдәшле рәвештә 3,5 һәм 6,3 тапкыр) үсә. Автоматлаштырылган идарә системаларын гамәлгә кертү җәелдерелә. Сәнәгый персонал арасында инженер-техник хезмәткәрләрнең өлеше 11% тан 16% ка кадәр арта. Бу җитештерүнең меңнәрчә эшче эшләгән берләшмәләр төзелүдә чагылыш тапкан катлаулы концентрация, специальләшү һәм кооперация процессларын тудыра, җитештерү процессларында теоретик белемнәрнең роле арту *фәнни-җитештерү берләшмәләре* оешуга китерә.

1970 еллар ахырыннан, СССРның барлык С. комплексындагы кебек үк, респ-ка С.ендә алгарыш б-н беррәттән тискәре күренешләр көчәя: җитештерүнең нәтиҗәлелеге түбәнәю, халык куллануы продукциясенең тиешле күләмдә җитештерелмәве күзәтелә. Моннан тыш 1980 елларда җитештерелгән продукция, респ-када бер кешегә күчереп исәпләгәндә, СССРдагы уртача күрсәткечтән өчтән бер өлешкә артыграк, әмма товарлар куллану һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану, социаль өлкә объектлары б-н тәэмин ителеш Союздагы һәм Россиядәге уртача дәрәҗәдән түбән була. С.нең алга таба үсеше 1980 елларның 2 нче яртысында башланган сәяси, икътисади һәм социаль реформалар б-н тыгыз бәйле. 12 нче бишьеллыкта (1986–90) пр-тиеләрнең мөстәкыйльлеге арта, хуҗалык эшчәнлегенең яңа формалары таралыш ала. 1990 да 524 С. пр-тиесе һәм берләшмәсенең 67 се аренда подряды тәртибендә эшли; аларның чагыштырмача өлеше гомуми сәнәгый продукция күләмендә 6,1%, сәнәгый-җитештерү персоналының гомуми исәбендә 5,4% тәшкил итә. Халык куллануы һәм җитештерү-техник юнәлеш продукциясен 21,6 мең кеше эшләгән 643 кооператив чыгара (продукциянең гомуми бәясе 283,5 млн. сум). Бу чорда С.кә социаль хасият бирү буенча беренче адымнар ясала, респ-ка төбәк хуҗалык исәбе принципларын эшләү башлана. 1990 елларда С.тә аеруча кискен үзгәрешләр була. Дәүләт заказы күп тапкырларга кыскару, СССР таркалу нәтиҗәсендә икътисади бәйләнешләр системасы җимерелү, пр-тиеләрне конверсияләү һәм диверсификацияләү өчен матди мөмкинлекләр булмау, салымнарның, чималга, җиһазларга һәм энергия чыганакларына бәяләрнең артуы, читтән кертелгән арзанлы товарларның көндәшлеге, халыкның сатып алу мөмкинлеге кимү сәнәгый җитештерү күләмнәренең катастрофик рәвештә түбән тәгәрәвенә китерә; 1990–94 тә Татарстанда аның иң зур күрсәткече 40%, ш.и. нефть химиясе С.ендә — 50%, ягулык С.ендә — 30%, урман, агач эшкәртү һәм целлюлоза-кәгазь С.ендә — 28%, электр энергетикасы һәм төзелеш материаллары җитештерүнең һәркайсында 26%, азык-төлек җитештерү С.ендә 20% тәшкил итә. Бу кризис аеруча машиналар төзү һәм металл эшкәртүдә (бигрәк тә оборона С.е комплексында) һәм җиңел С.тә тирәнәя һәм озакка сузыла: 1990–97 дә аларда җитештерү тиңдәшле рәвештә 63% ка һәм 71% ка кыскара. Җитештерүнең кимүе куәтләрнең тулысынча файдаланылмавына, С.тә эшләүчеләр санын күпләп кыскартуларга (1998 дә 397,6 мең кеше) китерә. Күп кенә пр-тиеләр бөлгенлеккә төшә һәм ябыла. 1995 тән продукцияне читкә чыгаруга йөз тоткан тармакларда (нефть чыгару, нефть химиясе С.те, агач эшкәртү), ш.у. азык-төлек, нефть-газ чыгару җиһазлары, җиңел автомобильләр җитештерүдә чагыштырмача үсеш башлана. Бу елларда респ-ка эчендә кооперация тирәнәюгә юнәлеш ала; күп кенә машина төзүче пр-тиеләр нефть-газ һәм нефть химиясе С.ләре өчен төрле җиһазлар эшләп чыгаруны үзләштерәләр.

1992 дә башланган *хосусыйлаштыру* барышында С.тә күп укладлы базар икътисадын барлыкка китергән киң колачлы үзгәрешләр була. 2006 га С. пр-тиеләрнең 73,6% ы хосусый милеккә күчә; аларның респ-ка С.ендәге өлеше: эшләүчеләр саны буенча — 39%, төп фондлар буенча — 19,1%, гомуми җитештерү күләме буенча — 36%. Пр-тиеләрнең 12,4% ы катнаш милектә була; респ-ка С.ендә аларга эшләүчеләрнең 42% ы, төп фондларның 71,1% ы, гомуми җитештерү күләменең 56%ы туры килә. Кече формалы пр-тиеләрнең саны шактый — 2,7 меңгә кадәр арта (30,6 мең кеше эшли); алар 14,1 млрд. сумлык продукция җитештерәләр, эшләр башкаралар һәм хезмәт күрсәтәләр. Интенсив рәвештә чит ил капиталы катнашындагы пр-тиеләр оештырыла; 2006 да ТРда җитештерү күләме 910 млн. һәм 224,2 млрд. сум булган 24 чит ил

пр-тиесе һәм 118 уртак пр-тие эшли. 1990 елларның 2 нче яртысыннан Татарстан пр-тиеләрендә җитештерүнең рентабельлеген күтәрү өчен эчке структураны оптимальләштерү, халыкара таләпләргә җавап бирүче сыйфат менеджменты системаларын гамәлгә кертү б-н бәйле актив процесслар бара. Холдинглар төзелә, С.кә стратегик инвесторлар (банклар һ.б. финанс ин-тлары, эре компанияләр) килә. Респ-кадагы күп кенә оборона С.е комплексы пр-тиеләрен интеграцияләү, ш.у. аларның федераль интеграцияләнгән структураларга керүе юнәлешендә эш алып барыла.

1990 еллар башында элек Союзга һәм Россиягә буйсынулы С. пр-тиеләренең зур өлеше ТР дәүләт органнары карамагына күчә (к. *Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация*, 1990; «*Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында шартнамә*», 1994). Моңа бәйле рәвештә индикатив идарә системасына нигезләнгән һәм салым ташламалары, кредитлар, инвестицияләргә дәүләт гарантияләре бирү, бурычларны реструктуризацияләү һәм финанс ягыннан савыктыру, чималга һәм энергия ресурсларына тарифларны көйләү, пр-тиеләрне чимал һәм заказлар (ш.и. дәүләт заказлары) б-н тәэмин итү, лизингның төрле формаларын файдалану, респ-ка эчендә һәм төбәкара кооперация җәелдерү, тышкы икътисади багланышлар урнаштыру юлы б-н җирле товар җитештерүчеләргә булышлык итүгә юнәлтелгән төбәк сәнәгый сәясәте активлаша. Россиянең башка төбәкләре б-н чагыштырганда, Татарстанда С.не хосусыйлаштыру акрынрак темпларда, дәүләтнең көйләүче роле шактый сакланган шартларда бара (базарга «йомшак» керү сәясәте). 1990 еллар ахырында җитештерүнең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм көндәшлеккә сәләтле югары өстәмә бәяле продукция чыгару максатында ТРның сәнәгый сәясәтендә кризис шартларында пр-тиеләргә ярдәм итүдән аларның инновацион үсешен стимуллаштыруга күчеш ясала. Даими рәвештә нефть-газ-химия комплексын, инновацион эшчәнлекне үстерү, энергияне һәм ресурсларны саклау, адреслы инвестицияләү, продукция сыйфатын күтәрү буенча максатчан респ-ка программалары эшләнә һәм гамәлгә ашырыла. Түбән Камада дәүләт булышлыгы б-н яңа нефть эшкәртү һәм нефть химиясе пр-тиеләре төзелә. 2006 да респ-ка дәүләт идарәсе органнары тарафыннан төп юнәлеш сыйфатында С.нең кластерларга кергән эре пр-тие-үзәкләрне комплектлаучы эшләнмәләр һәм иярчен продукция б-н тәэмин итүче вак һәм уртача зурлыктагы оешмалар, фәнни-техник, финанс-кредитлаучы учреждениеләр, уку йортлары б-н үзара бәйләнешләренә нигезләнгән, төп тармаклар үсешендә өстәмә нәтиҗә бирүче кластерлы үсеш стратегиясе билгеләнә. Татарстанда нефть химиясе һәм автомобиль кластерлары барлыкка килә, энергетика, урман С.е, көнкүреш техникасы җитештерүчеләр кластерлары оеша. Респ-када зур фәнни-техник һәм мәгариф потенциалы туплану С. үсеше өчен уңайлы шартлар тудыра. Кече һәм урта эшмәкәрлекнең югары технологияле продукция җитештерүдә катнашуын активлаштыру өчен, респ-када *технопарклар* челтәре формалаша, аңа «Идея» (Казан), «Восток» (Чистай) инновацион-җитештерү технопарклары, Кама «Мастер» индустриаль паркы (Чаллы һәм ТР районнарындагы шундый ук 12 мәйданчык), «Химград» технополисы (Казан), Түбән Кама сәнәгый округы һ.б. керә. Чит илләр инвестицияләрен җәлеп итү өчен, «Алабуга» аерым икътисади зонасы ачыла. Структур реформалар, уйланылган сәнәгый сәясәт, оешмаларның яңа шартларга яраклашуы, продукциянең яңа төрләренә күчү, икътисади конъюнктура үзгәрү нәтиҗәсендә 1990 еллар ахырыннан С. тармакларының күпчелек өлешендә тотрыклы үсеш тенденциясе күзәтелә.

2013 тә Татарстан С.ендә 8,5 меңнән артык оешма һәм аларның терр. аерымланган бүлекчәләре (ш.и. 631 эре һәм уртача зурлыктагы пр-тие) исәпләнә, төп фондларның бәясе 1007,7 млрд. сум, эшләүчеләр саны 399,5 мең кеше (тиңдәшле рәвештә респ-кадагы барлык төп фондларның һәм эшләүчеләрнең 59,7% ы һәм 22% ы) тәшкил итә. С. пр-тиеләре 1549,2 млрд. сумлык продукция җитештерәләр, эшләр башкаралар һәм хезмәт күрсәтәләр. Продукциянең тармаклар буенча бүленеше: эшкәртү — 68,5%, чыгару-җитештерү — 23,7%, электр энергиясе, газ һәм су җитештерү, бүлү — 7,8%, файдалы ягулык-энергетика казылмалары чыгару — 23,6%, химия һәм нефть химиясе продукциясе — 17,4%, транспорт чаралары һәм җиһазлар җитештерү — 20,3%, нефть продуктлары — 7,3%, азык-төлек продуктлары һәм эчемлекләр — 6,8%. ТР икътисадының барлык керемнәренең 77,8% ын С. бирә. С. экспортын 22,4 млрд. АКШ доллары тәшкил итә, шуның 20,8 млрд.ы — ерак, 2,2 млрд.ы якын чит илләргә туры килә. С.нең төп капиталына 179,1 млрд. сум, ш.и. эшкәртүгә — 64,8%, табу-чыгаруга — 22,7%, электр энергиясе, газ һәм су җитештерү, бүлүгә 12,2% инвестицияләнә. Соңгы елларда гомуми продукция, читкә чыгару һәм инвестицияләр күләмендә эшкәртү тармакларының өлеше тотрыклы рәвештә үсә бара. Шул ук вакытта респ-ка С.ендә күп кенә проблемалар бар: С. продукциясен читкә чыгаруда чимал юнәлеше өстенлеге (50% чамасы чи нефтькә туры килә), алга киткән илләр б-н чагыштырганда, өстәмә бәяле продукция җитештерү үсешенең, хезмәт җитештерүчәнлеге һәм рентабельлелекнең, үзкыйммәтне, энергия һәм ресурслар сарыф итүне киметүнең түбән күрсәткечләре саклана. Тармакларда эшчеләр хезмәтенә түләүдә шактый зур аерма күзәтелә: 2013 тә уртача хезмәт хакы чыгару-җитештерү тармакларында — 41,2 мең сум, эшкәртүдә — 26,4 мең, электр энергиясе, газ һәм су җитештерү, бүлүдә 32,9 мең сум тәшкил итә.

2014 тә продукция күләме арту бигрәк тә приборлар төзү, нефть химиясе, нефть эшкәртү, автомобильләр төзү тармакларында югары була. С. җитештерүнең күләмнәре буенча Татарстан РФ төбәкләре арасында Идел буе федераль округында 1 нче һәм илдә 5–6 нче урыннарны били.

Чыг.: Ведомость о фабриках и заводах Казанской губернии за 1900 год. К., 1901; История Татарии в материалах и документах. М., 1937; Индустриализация Татарской АССР. 1926–1941: Док. и материалы. К., 1968; Промышленность и рабочий класс Татарии (1946–1980): Док. и материалы. К., 1986; Республика Татарстан. 1920–2000: Стат. сб. К., 2001.

*Әд.:* Материалы по истории Татарии. К., 1948. Вып. 1; З а й ц е в А.И. Подъём экономики и культуры Татарии за 40 лет. К., 1957; А з и з о в К.И. Промышленность Татарии и пути повышения её эффективности. К., 1973; Н а з и п о в а К.А. Национализация промышленности в Татарии (1917–1921 гг.). М., 1976; Г и л ь м а н о в З.И. Татария в Великой Отечественной войне 1941–45 гг. К., 1977; Б е л я л о в У.Б. Руководство Коммунистической партии социалистической индустриализацией в национальных республиках Среднего Поволжья (1926–1940 гг). К., 1978; Рабочий класс Татарии (1861–1980 гг.). К., 1981; Проблемы истории рабочего класса Татарии: Сб. статей. К., 1984; Золотые страницы купечества, промышленников и предпринимателей Татарстана: В 2 т. К., 2001; К а л и м у л л и н А.М. Природоохранные проблемы в контексте индустриального развития Татарстана в 1960-х — начале 1990-х годов. К., 2005; Г а т а у л л и н а - А п а й ч е в а И.А. Среднее Поволжье в годы экономической политики: социально-экономические процессы и повседневность. К., 2007.

*С.Г.Белов, Г.Я.Мәүлетова.*

**СӘНӘГА́ТЬ ҺӘМ АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ КҮРГӘЗМӘЛӘРЕ́** (Казанда). Россиядә илнең сәнәгать, сәүдә һәм а.х. өлкәсендәге казанышларын тәкъдим итү өчен күргәзмәләр үткәрү турындагы карар Россия хөкүмәте тарафыннан 1828 елда кабул ителә. 1829 да С.-Петербургта Россиядә беренче сәүдә-сәнәгать күргәзмәсе уздырыла. 1836 да, тәхет варисы — патша улы Александр Николаевичның Россия буйлап сәфәре уңаеннан, Эчке эшләр министрлыгы губернаторларга губерна күргәзмәләре оештыру өчен гомуми план юллый. Әлеге күргәзмәләрнең максаты булачак патшаны губерналарның икътисади тормышы б-н таныштыру, урыннарда сәнәгать һәм сәүдәне үстерүгә булышлык итү була. Губерна күргәзмәләрендә, сәнәгатьтә җитештерелгәннәрдән тыш, а.х. эшләнмәләре дә тәкъдим ителә, бу Казанда шуннан соң узган барлык сәнәгать күргәзмәләренең дә үзенчәлегенә әверелә. Казанда беренче мануфактура күргәзмәсе 1837 нең 1 июнендә Шәһәр җәмгыять йортында ачыла. Тәкъдим ителгән эшләнмәләр 4 категориягә бүленә: «хайваннар дөньясы эшләнмәләре» (завод-фабрикаларда эшләнгән әйберләр, мәс., Г.И.Осокин ф-касының куе яшел һәм соры постаулары, сәүдәгәр Х.М.Апанаев з-дының каҗул һәм сафьян күн эшләнмәләре, терлек маеннан ясалган шәмнәр, кер сабыны һәм исле сабыннар, төрле тиреләр; һөнәрчелек эшләнмәләре: озын кунычлы, кыска кунычлы күн итекләр, читекләр, алтын һәм көмеш б-н чигелгән энҗеле калфак-түбәтәйләр, фил сөяген кырып ясалган эшләнмәләр; а.х.нда җитештерелгән эшләнмәләр (келәмнәр, ат ябмалары, йон әйберләр һ.б.); «казылмалар дөньясы эшлән-

мәләре» (корыч коелмалар, чаңнар, кызыл штык бакыры, фонарьлар, комганнар, көнкүреш әйберләре, балдаклар, алкалар һ.б.); «үсемлекләр дөньясы эшләнмәләре» (кытат, комач тукымалар, поташ, тәмәке, май, татлы тамыр, киндер тукыма һ.б.); гадәти һәм сәнгати әйберләр (мәс., К.Ф.Фукс — Казан губернасының төрле бөҗәкләре коллекциясен һәм майлы буяу б-н ясалган Болгар хәрабәләре күренешләрен, барон Келлер аю, болан һ.б. хайван карачкыларын тәкъдим итәләр). 1842 дә хөкүмәт губерна а.х. продуктлары күргәзмәләре уздыру турында карар кабул итә; күргәзмәләрнең, нигездә, крәстиян катлавыннан булган хуҗаларга өстенлек бирүгә юнәлдерелергә тиешлегенә басым ясала. Беренче а.х. күргәзмәсе 1845 нең 5–15 маенда Казанның Шәһәр җәмәгать йортында уздырыла. Казан губернаторы, а.х. эшләнмәләре җитәрлек булмау сәбәпле, з-д һәм мануфактура эшләнмәләрен дә кабул итәргә рөхсәт бирә (әлеге рөхсәт башка а.х. күргәзмәләрендә дә көчендә калдырыла). Күргәзмә б-н җитәкчелек итү өчен аерым вакытлы ком-т төзелә, аңа губерна дворяннары башлыгы, Дәүләт мөлкәте палатасы идарәчесе, Император ирекле икътисади җәмгыятенең 2 әгъзасы — Н.И.Лобачевский һәм Н.И.Депрейс, полицмейстер һәм шәһәр башлыгы кертелә; директор итеп полковник И.К.Якобий билгеләнә. Күргәзмәдә 498 «сандагы әйбер» тәкъдим ителә; күпчелекне игенчелек продуктлары (бөртекләләр, бәрәңге һ.б.) һәм һөнәрчелек эшләнмәләре (балта, сука, чапкыч, тәгәрмәчләр һ.б.) тәшкил итә. Үз продукцияләрен күргәзмәгә куйган крәстияннәргә көмеш б-н 25, 15 һәм 10 сум (барлыгы 400 сум) премия өләшенә; сәүдәгәр М.С.Зайцев һәм фабрикант Б.Адамовка — иң яхшы кытат тукыма өчен, сәүдәгәр А.И.Котелов һәм мещан Колановка — итеклек кәҗүл тиреләр өчен, мещан Леонтьевка мездра җилеме өчен мактау кәгазе бирелә; затлы башмак күне һәм кәҗүл товарлар өчен П.И.Котелов — алтын, иң югары сыйфатлы бәрәңге балы (патока) өчен Н.И.Депрейс һәм терлек маеннан ясалган иң яхшы шәмнәр өчен П.И.Докучаев көмеш медаль б-н бүләкләнәләр. Реформадан соңгы чорда Казанда 9 күргәзмә: 1866, 1880 дә — а.х., 1888, 1889, 1893 тә — чәчү орлыгы, 1886 да — *фән-сәнәгать күргәзмәсе*, 1870, 1880 дә шәхси сәнәгать һәм а.х. күргәзмәләре оештырыла. Елдан-ел халыкта күргәзмәләр б-н кызыксыну көчәя бара, экспонатлар саны да (беренче күргәзмәләрдә йөзләрчә тәр булса, гасыр ахырында — меңнәрчә), бүләкләр саны да (1866 да — 67, 1890 да 1278 бүләк тапшырыла) арта; 1866 елдагы күргәзмәгә 350 кеше килсә, 1890 елдагысын 125 мең кеше карый. Күргәзмәләр уздыру традициясе 20 йөздә дә дәвам итә (к. *Татарстан АССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе*).

Чыг.: История Казани в документах и материалах. XIX век: Промышленность, торговля, финансы. К., 2005.

*Л.М.Айнетдинова.*

**СӘНӘГЫ́Й ТӨЗЕЛЕ́Ш**, *сәнәгатьнең* төп фондларын булдыручы төзелеш тармагы. С.т.нең бурычлары — төзү һәм монтажлау эшләренең тулы комплексын башкару, пр-тиеләрнең яңаларын файдалануга тапшыруны тәэмин итү, гамәлдәгеләрен киңәйтү һәм реконструкцияләү.

Казанда сәнәгый максаттагы беренче биналар 18 йөз башында барлыкка килә (*Помпа каеш-күннәре заводы, Казан постау мануфактурасы* һ.б.). Аларның берсе — *Казан адмиралтейтсвосы* капкалы манаралар корылган имән диварлар һәм канал б-н әйләндереп алынган, периметр буенча урнашкан берничә бинадан торган зур утар-верфьтән гыйбарәт була.

18 йөз уртасындагы янгыннан соң постау мануфактурасының җитештерү биналары кирпечтән салына. 1753 елда уникаль конструкцияле — ун метрлы гөмбәз түбәсе идәннән үк диярлек күтәрелгән, тимер арканнар б-н беркетелгән баганасыз-терәксез бина төзелә; ул — Татарстанда 18 йөздән сакланып калган бердәнбер сәнәгать төзелеше истәлеге. Шулай ук төп бина б-н зур утарны әйләндереп алган дүртпочмаклык хасил иткән казармалар корыла. Казан дары з-дын төзегәндә киң колачлы эшләр башкарыла. 1786–87 дә аның төзелеш мәйданында, башлыча, кирпеч, нигездә, 20 дән артык — агач, 19 йөз башында 30 дан артык капиталь кирпеч бина төзелә. Пр-тиеләр тирәсендә Постау, Адмиралтейство, Дары бистәләре барлыкка килә.

Сәнәгый борылыш һәм җитештерүне механикалаштыру С.т. алдында яңа таләпләр куя. Җитештерү биналары алар эчендә пар двигательләре, локомобильләр, электр двигательләре һ.б. зур җиһазлар урнаштыру зарурлыгы исәпкә алынып төзелә башлый. Эре фабрика-завод комплекслары оештырыла. Мәс., 1855 тә нигезләнгән *Шәм-стеарин, сабын кайнату, глицерин җитештерү химия заводы* 1870 кә 100 дән артык корылма, ш.и. 5 күпкатлы ф-ка корпусы урнашкан 22 *га* дан артык мәйданны били. В.Л.Челышевның Чистай шәһәрендәге ике катлы озынча тегермән һәм ярма яргыч бинасын, бер катлы суыту корпусын, ике катлы склад биналарын үз эченә алган пар тегермәне комплексы (1873 — 20 йөз башы) азык-төлек җитештерү сәнәгате пр-тиеләре арасында сәнәгать архит-расының типик истәлеге булып тора. Барлыкка килгән яңа тип конструкцияләр исәбенә, мәс., И.И.Алафузов җитен-туку ф-касының күп метрлы торбасы (1890 еллар), Нурлат һәм Ютазыдагы тимер юл станцияләрендәге су кудыру башнялары (1909–11), Чаллы элеваторының җиде яруслы тимер-бетон башнясы һәм тоташтыру галереялары (1917) һ.б. керә. 1900 дә Казанда Россиядә беренчеләрдән булган 3 үтү капкалы махсус трамвай депосы бинасы төзелә. 19–20 йөзләр чигендә сәнәгать архит-расында кирпеч эклектикасы стиле өстенлек итә.

Барлык төзелеш эшләре сезонлы булып, башлыча, аерым затлар һәм артельләр тарафыннан башкарыла. Эш катлаулы булганда һәм күп хезмәт таләп иткәндә, төрле белгечләрдән (ташчылар, балта осталары, түбә ябучылар, пыялачылар һ.б.) «компанияләр» оештырыла. Еш кына тирә-яктагы авыллардан үз хезмәт кораллары һәм эш терлекләре б-н крәстияннәр җәлеп ителә.

1921 дә Казандагы кустарь остаханәләр 1 нче һәм 2 нче универсаль төзелеш конторалары составына кертелә, 1922 дә алар «Госуниверстрой» конторасына (7 берәмлек су транспорты, 46 ат, Печище авылы янындагы ак таш карьеры) берләштерелә. Контораның төп бурычы сәнәгать объектларын төзү һәм реконструкцияләүдән гыйбарәт була. Аңа башкару йөкләнгән тәүге проектларның берсе — Казандагы һәм Бондюгтагы Гражданнар сугышы вакытында җимерелгән з-дларны реконструкцияләү. 1920 еллар ахырыннан ТАССРда, бөтен илдәгечә, *индустрияләштерү* процессында тизләтелгән яңа фабрика-заводлар төзү сәясәте уздырыла. «Госуниверстрой» 1925 тә — «Татстрой», 1927 дә «Казгосстройконтора» итеп үзгәртелә. 1929 да Татарстанда сәнәгатьнең әйдәүче тармакларында төзелеш һәм реконструкцияләү планы төзелә. 1 нче бишьеллыкта (1929–33) 26 фабрика һәм завод (293 млн. сум капитал салу), ш.у. респ-када куәтле җылылык электр станциясе төзү күздә тотыла. Төзелештә мәшгуль халыкның шактый өлешен сезонлы эшчеләр тәшкил итә. 1932 дә Магнитогорск шәһәре төзүчеләре тәҗрибәсе буенча ел әйләнәсе эшләүгә күчеш ясала.

1930 елларда, авыр индустрия үсеше һәм энергетика куәтләре арту нәтиҗәсендә, төзелеш оешмалары структурасында үзгәрешләр була. Авиация комб-тын төзү өчен — «Авиастрой» оешмасы, Дербышки посёлогында 237 нче з-дны төзү өчен Капиталь төзелеш идарәсе «Казанпромстрой» тресты (Йошкар-Ола шәһәрендәге «Марпромстрой», Волжск шәһәрендәге «Марбумстрой» конторалары б-н) оештырыла. 1930 еллар ахырында Казанда эшләгән күпсанлы төзелеш оешмалары тармак буенча Кораллану, Авиация һ.б. халык комис-тларына буйсына. Бу чорда С.т.тә индустриаль алымнар (ш.и. эре панельле төзелеш — 1934 тән) гамәлгә кертелә, яңа төзелеш материаллары (бетон, тимер-бетон), машиналары һәм механизмнары (измә туглагычлар, бетон туглагычлар, измә насослар һ.б.) кулланыла башлый. Индустрияләштерү барышында Татарстанда 70 тән артык эре, 300 ләп уртача зурлыктагы һәм вак пр-тиеләр төзелә.

Бөек Ватан сугышы башлану б-н, күп кенә гражданлык объектларында эшләр туктала. Тиз арада эвакуацияләнгән з-дларны эшләтеп җибәрү һәм хәрби сәнәгать комплексының яңа куәтләрен (авиация з-длары, 230, 237, 294 нче з-длар, Казан төгәл машиналар төзү з-ды һ.б.) эшкә җигү таләп ителә. 1941–45 тә 22 пр-тие төзелә.

Сугыш тәмамланып, таркалу хәлендәге җитештерү һ.б. максатлардагы объектлар торгызылганнан соң, яңа төзелешләр җәелә. Казанда компрессорлар, электромеханика, җылылык үлчәү приборлары һәм автоматлаштыру чаралары (хәзер «Теплоконтроль»), трактор моторлары ремонтлау һәм а.х. машиналары өчен запас частьлар (хәзер «Вакуummаш» һ.б.) з-длары төзелә.

Нефть чыгару сәнәгате барлыкка килү б-н, нефть чыганакларын җиһазлау буенча төзелеш-монтаж конторасы булдырыла (1945). 1949 да Бөгелмә шәһәрендә Татарстан терр. төзелеш идарәсе (ТТСУ) оештырыла, аның составына төзелеш индустриясенең респ-каның көньяк-көнчыгышындагы барлык төзелеш, механикалаштырылган, автотранспорт оешмалары һәм пр-тиеләре керә. Шәһәр тибындагы Баулы, Карабаш посёлокларында, Әлмәт шәһәрендә нефть өчен 100, 200, 400 *м³* сыешлы резервуарлар, нефть промыселлары товарлыклы паркларының беренче чиратлары, Бөгелмә шәһәрендә һәм Әлмәт р-нының шәһәр тибындагы Рус Акташы, Түбән Мактама посёлокларында беренче насос һәм электр дегидрон җайланмалары, кирпеч з-длары корыла. 1954 тә ТТСУ җирлегендә «Бөгелмәнефтьстрой» (хәзер «Стройтрест» АҖ), «Ромашкинонефтьстрой» (соңрак «Лениногорскнефтьстрой») һәм «Әлмәтнефтьстрой» (хәзер «Татнефтьгазстрой» АҖ составында) трестлары оештырыла. Алар тарафыннан Бөгелмәдә механика һәм тимер-бетон эшләнмәләр, Миңлебайда газ эшкәртү, Лениногорскида автоматлаштыру чаралары һәм нефть җиһазларын ремонтлау, Әлмәттә спираль җөйле торбалар һәм тутыру электр насослары з-длары җитештерү куәтләре, шәһәр тибындагы Тихоновка, Миңлебай, Карабаш, Азнакай посёлокларында товарлыклы парклар һ.б.; нефть, газ һәм химия сәнәгате өчен магистраль газүткәргечләрдә насос, компрессор, газ кудыру станцияләре, торба үткәрүле магистральләр һ.б. объектлар төзелә.

1950 елларның 2 нче яртысында респ-када эре җитештерү объектлары, ш.и. Казанда «Теплоконтроль», «Искож», матем. машиналар, «Сантехизделия» з-длары, химия, мех комб-тлары, ТЭЦ-1, ТЭЦ-2, төзелеш индустриясе һәм төзелеш материаллары сәнәгате, азык-төлек җитештерү сәнәгате объектлары һ.б. төзелә һәм киңәйтелә. Бу эшләр барышында 1950 еллар ахырында 3 нче төзелеш-монтаж тресты (соңрак «Казанпромстрой» тресты) булдырыла. 1956 да Татарстан ХКС составында Төзелеш идарәсе оештырыла; ул төрле министрлыклар карамагындагы барлык җирле төзелеш оешмаларын берләштерә, нәтиҗәдә эшләрнең күләме арта. 1958 дә, респ-када химия сәнәгате үсешенә бәйле рәвештә, «Химэнергострой» тресты (1963 тән «Казанхимстрой») төзелә, ул Казанда органик синтез, химия, «Полимерфото», фотожелатин з-дларын, дару препаратлары, җөй-хирургия материаллары пр-тиеләре комплексын һ.б.ны төзүдә катнаша. Казан органик синтез з-ды төзелеше күп катлы биек, зур күләмле химия аппаратлары корыда индустриаль алымнар куллану мәктәбе була.

1960 еллар башында капиталь төзелеш күләменең үсә баруын тәэмин итү максатында союз һәм респ-кага буйсынулы яңа төзелеш оешмалары һ.б. төзелеш комплексы структуралары, ш.и. Түбән Кама шәһәрендә нефть химиясе пр-тиеләре төзү өчен *«Татэнергострой»*, Түбән Кама ГЭСын төзү өчен *«Камгэсэнергострой»*, эчке сантехниканы монтажлау һәм тышкы коммуникацияләрне сузу эшләрен башкару өчен «Казанспецстрой» тресты, ш.у. элек гомумтөзелеш трестлары составында булган механикалаштыру базаларын берләштергән «Строймеханизация-3» тресты төзелә.

1965 тә Казанда энергетика объектларын төзү мәсьәләләрен хәл итү өчен 5 нче төзү-монтаж идарәсе (хәзер «Теплоэнергострой-2» төзелеш идарәсе АҖ) оештырыла. Аның тарафыннан ТЭЦ-3 корыла, куәтләре арттырылып, ТЭЦ-1 һәм ТЭЦ-2 реконструкцияләнә, магистраль җылылык үткәргечләр, югары басымлы газүткәргечләр сузыла, газ бүлү пунктлары урнаштырыла һ.б. 1968 дә, Зеленодольск суднолар төзү з-дында, Серго исем. з-дта төзелеш күләме арту һәм торак-гражданлык объектларын төзүгә заказлар күбәю сәбәпле, 3 нче төзү-монтаж тресты (хәзер Сәнәгать-төзелеш фирмасы) булдырыла.

1970 тә СССР Сәнәгать министрлыгына буйсынудагы эре респ-ка төзелеш комплексы — Баш төзелеш идарәсе («Главтатстрой») оештырыла. 1970–90 елларда респ-када капиталь төзелеш буенча гаять зур күрсәткечләргә ирешелә. Гамәлдә төзелеш һәм реконструкция халык хуҗалыгының барлык тармакларында алып барыла. 60 тан артык эре пр-тие сафка бастырыла. 1929–90 да барлык 232 эре сәнәгать һәм төзелеш индустриясе пр-тиесе төзелә. Илне индустрияләштерү нәтиҗәсендә күбрәк җыелма, тимер-бетон, корыч конструкцияләр, панельләр кулланыла башлый. «Татнефть» ҖБндә нефть промыселлары җир өсте корылмаларын блоклап төзү киң җәелә, респ-када беренче тапкыр электр б-н эретеп ябыштыру, торбаларны автоматлаштырылган өзлексез линияләрдә чистарту һәм изоляцияләү үзләштерелә. «Түбәнкаманефтехим» ҖБн төзегәндә уңышлы рәвештә, әүвәл узелларны җирдә җыеп, эре блоклар рәвешендә монтажлау кулланыла һәм дөньяда беренче тапкыр төзү-монтаж һәм сафка кертү-көйләү эшләре берьюлы башкарыла. Кама автомобиль з-дын төзү вакытында яңа төзелеш конструкцияләре һәм технологияләре, ш.и. субайлар кагып нигез салу, җыю һәм монтажлауның конвейер алымы гамәлгә кертелә, нәтиҗәдә, өлешләп монтажлау б-н чагыштырганда, хезмәт җитештерүчәнлеге күпкә арта, төзелеш вакыты кыскара, үзкыйммәт кими һәм төзү-монтаж эшләренең сыйфаты яхшыра. Әмма төзелеш материаллары, техника, җиһазлар һәм квалификацияле төзелеш планнары һәрвакытта да үтәлми. Еш кына С.т. тиешенчә фәнни, техник-икътисади һәм экологик яктан нигезләнмичә алып барыла.

1990 елларда җитештерүнең кимүе пр-тиеләр тарафыннан һәм дәүләт бюджетыннан капиталь төзелешкә юнәлтүле финанс чараларының азаюына китерә. Респ-када инвестицияләү активлыгының түбәнәюенә бәйле рәвештә җитештерүгә йөз тоткан объектлар төзүгә заказлар кыскара. Җитештерү өлкәсенә капитал салулар б-н, башлыча, пр-тиеләр һәм оешмалар үзләре шөгыльләнә; 1995 тә файдалануга 12 сәнәгать бинасы тапшырыла. Төзелеш индустриясе пр-тиеләре күпләп торак һәм социаль-мәдәни, көнкүреш объектлары төзүгә юнәлеш ала. Соңгы елларда С.т.кә инвестицияләр күләме яңадан арта (ш.и. җәлеп ителгән акчалар хисабына да). Соңгы елларда эре сәнәгать пр-тиеләре: «ТАИФ-НК» АҖ бензин з-ды, «ТАНЕКО» АҖ нефть эшкәртү з-длары комплексының беренче чираты, тоташ металл кордлы шиннар з-ды (барысы да Түбән Камада), «ИНВЕНТ» компанияләр төркеменең кабель, электр техникасы һәм торбалар продукциясен җитештерүче з-длары, «Нәфис» компанияләр төркеменең май экстракцияләү һәм май з-длары (барысы да — Казанда), «Алабуга» аерым икътисади зонасындагы нефть химиясе, автомобиль продукциясе, төзелеш материаллары җитештерүче пр-тиеләр.

2013 тә сәнәгый максатлардагы 129 бина (гомуми мәйданы — 198253 *м²*) файдалануга тапшырыла, дизель ягулыкны гидрочистарту (елга 2 млн. *т*), газ эшкәртү (елга 140 млн. *м³*), кирпеч җитештерү (елга 5 млн. данә) куәтләре сафка баса.

Татарстан төзелеш комплексы барлыкка килү һәм үсешенең барлык этапларында проектлау оешмалары мөһим роль уйный. Аларның иң зурысы — ГипроНИИавиапром, ул 1941 дә самолётлар һәм авиация двигательләре җитештерүне оештыру б-н бәйле эшләрне башкару өчен махсус проектлау бригадасы (СПБ-6) буларак оештырыла. Хәзерге вакытта институт ген. проектлау оешмасы вазифаларын башкара, сәнәгатьнең төрле өлкәләренә караган пр-тиеләрне һәм торак-гражданлык объектларын комплекслы проектлауны пр-тиеләр, биналар һәм корылмалар төзелешенә, әйләнә-тирәне саклауга, биналар һәм корылмаларның техник торышын тикшерүгә инвестицияләрнең нигезләмәләрен эшләүне гамәлгә ашыра. 1950 дә Казанда «Татнефтьпроект» проект конторасы (хәзер «Нефтьхимпроект» АҖ) — «Татнефть» берләшмәсенең структур подразделениесе төзелә, ул нефть чыганакларын комплекслы җиһазлау объектларын төзү һәм реконструкцияләү буенча проектлау-смета документларын эшләү, нефтьне кабул итү, саклау, әзерләү объектларын проектлау б-н шөгыльләнә. 1987 дә, исәпләү техникасы һәм информатика пр-тиеләрен проектлау өчен, Казанда «ГИПРО ВТИ» ин-ты оештырыла.

*Әд.:* Советской Татарии 40 лет. К., 1960; Нефть, газ и нефтехимия Татарии. К., 1979. Т. 2; История Казани: В 2 кн. К., 1988–91; Анализ и основные направления развития и размещения производительных сил Республики Татарстан. К., 1996; Республика Татарстан. 1920–2000: Стат. сб. К., 2001; Архитектурно-строительный комплекс Республики Татарстан: История, биография, свершения, надежды. К., 2005.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**«СӘНӘ́К»**, айлык сатирик һәм юмористик журнал. ВКП(б)ның Башкортстан өлкә ком-ты органы. 1926–37 елларда Уфа шәһәрендә татар телендә *«Яңа авыл»* г-тасына кушымта буларак нәшер ителә. «Авызың чалыш булса, көзгегә үпкәләмә» дигән лозунг б-н чыга. «Октябрь кысрыклавы» басмаханәсендә басыла. Мөхәррире — И.Насыйров, нашире — «Коммуна» г-тасы. Беренче елларда авторлар — псевд. б-н (Кармак, Комсомол, Снайпер һ.б.), соңрак үз исемнәрен күрсәтеп (М.Гаделев, Г.Гомәр, Х.Ф.*Искәндәров*,

В.Мадал, Г.Сабир һ.б.) язалар. «С.»тә совет төзелешенә чит булган күренешләрдән, ришвәтчелек, хуҗасызлык, хулиганлык, культурасызлык, эленке-салынкылык һ.б.дан көленә. Фельетоннар, памфлетлар, шигырьләр, әдәби пародияләр дөнья күрә. Укучыларның тәнкыйди хатларына аерым игътибар бирелә. Еш кына язмалар А.Гафури, С.Шәфиев һ.б.ның рәсемнәре һәм карикатуралары б-н бирелә; Г.Әмири, З.Бәшири, М.Крымов, Сәйфи Кудаш, А.Сатыш һ.б.ның шигырьләренә шаржлар басыла.

1926 да 11 нче санынннан журнал төсле итеп нәшер ителә. «С.» рев-циягә кадәрге татар юмористик журналистикасы традицияләрен дәвам итүче булып тора, көлке образлар эшләүгә үзеннән өлеш кертә. «С.»тә публицистик һәм әдәби сатираның уңышлы ярашуы милли сатира принципларын раслауга һәм татар-башкорт сатирик журналистикасы барлыкка килүгә ярдәм итә.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом): 1905–1925. К., 1926; Г ы й м а д и е в Ү. Сатира теориясе мәсьәләләре. Уфа, 1984.

**«СӘНӘКЧЕЛӘ́Р» ФЕТНӘСЕ́**, 1920 елда Уфа губернасы Минзәлә, Уфа, Бәләбәй, Бөре өязләре, Казан губернасы Чистай өязе, Самара губернасы Бөгелмә өязе крәстияннәренең хөкүмәткә каршы күтәрелеше. Крәстияннәр *продразвёрстка* авырлыгына һәм азык-төлек отрядларының башбаштаклыгына карата ризасызлык белдерәләр. «С.»ф. Минзәлә өязенең Яңа Алан авылы халкы чуалышыннан башланып китә. 4 февраль көнне авылга Минзәлә өязенең азык-төлек ком-ты вәкиле Пудов җитәкчелегендә 35 кешедән торган азык-төлек отряды килә. Крәстияннәрдән продразвёрстканың 100% үтәлүен таләп итеп, вәкил авылда хәрби хәл кертелеүен белдерә һәм 20 кешене кулга ала. Кулга алынганнарны азат итү таләбе Пудов тарафыннан кире кагылганнан соң, 7 февральдә крәстияннәр азык-төлек отрядының бер өлешен юк итәләр һәм, көрәшкә күтәрелергә өндәп, авылларга үз вәкилләрен юллыйлар. Минзәлә гадәттән тыш комиссиясе рәисе М.С.Головин җитәкчелегендә крәстияннәр чуалышын бастырырга килгән отряд тар-мар ителә. Февраль уртасына фетнә Минзәлә өязенең күпчелек волостьларын, Уфа губернасы Уфа өязенең — 10, Бәләбәй өязенең — 22, Бөре өязенең — 15, Казан губернасы Чистай өязенең — 15, Самара губернасы Бөгелмә өязенең 16 волостен чолгап ала. Үзәге Зәй шәһәрендә булган фетнә штабы оештырыла. Аңа элеккеге офицерлардан Никонов, Крапивин, Шимановский, Юсуповский, фельдфебель Милованов керә. Баш күтәрүчеләрнең Чистай-Казан (җитәкчесе Седов), Минзәлә (Милованов), Бөгелмә-Самара (Васякин) «фронтлары» төзелү турында игълан ителә. Архангельский, Акбүре, Петропавловский бистәләре, Аккирәй, Ялантау, Зирекле, Акташ, Бота, Шуган, Тәкмәк, Яңа Чишмә авыллары чуалыш үзәкләренә әверелә. Баш күтәргән крәстияннәрнең анык программалары булмый, алар «Бетсен коммунистлар!», «Яшәсен иректе сәүдә!», «Бетсен гражданнар сугышы!», «Крәстияннәр хакимияте өчен!»,

КАЗАН ГУБЕРНАСЫНДА 1920 елгы «СӘНӘКЧЕЛӘР» ФЕТНӘСЕ




«Бетсен коммунистлар, яшәсен Кызыл Армия!», «Яшәсен большевиклар һәм иректе сәүдә!» кебек лозунглар б-н чыгалар. Фетнәчеләргә каршы Респ-каның запас армиясеннән 5 оператив төркем (тулай саны — 6372 штык, 816 кылыч) җибәрелә, алар Чистай, Минзәлә, Бөгелмә өязләре аша Бөгелмә һәм Уфа шәһәрләре юнәлешендә хәрәкәт итә. «С.»ф.н бастыру барышында 600 дән артык баш күтәрүче үтерелә, 5235 кеше кулга алына. Бөгелмә өязендә 1276 кешедән торган респ-ка эчке сак хезмәте гаскәрләре баш күтәргән крәстияннәрне җиңелүгә дучар итә. «С.»ф.нә каршы көрәшкә ш.у. Төркестан фронты гаскәрләре дә тартыла. Март урталарына фетнә тулысынча бастырыла. Баш күтәрүчеләр ягыннан югалтулар — 3 меңгә якын кеше, совет хезмәткәрләре, кызылармиячеләр һәм аларның гаилә әгъзалары арасыннан 800 кеше тәшкил итә.

*Әд.:* Л и т в и н А.Л. Крестьянство Среднего Поволжья в годы гражданской войны. К., 1972; Т а г и р о в И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**СӘНГАТИ́ ТУКУ́**, тукымаларны туку станында әзерләү; гамәли-бизәлеш сәнгате төре. Татар халык иҗатының борынгы төре (туку, сугу). Берничә этаптан тора: чималны (сарык йоныннан, киндердән, җитеннән, сирәк кенә — кычытканнан, 19 йөзнең 2 нче яртысыннан — ф-каларда әзерләнгән киҗе-мамык җептән) беренчел эшкәртү, эрләгән җеп (сортларга аеру, йон эрләү һәм җепселләрне буяу) һәм алардан тукыма әзерләү. Җеп эрләү өчен орчык, җеп эрләгеч һәм җеп эрләү машинасы, аеруча җыелма эрләгеч киң кулланыла (төп һәм калак өлешләрдән тора). Эрләгән җепне буяу өчен 19 йөз уртасына кадәр — үсемлек (ат кузгалагы яфраклары, имән, зирек каерысы, сары буяк), 19 йөз ахырыннан химик буяулар кулланылган. Тукымалар кулдан, туку станында аркау һәм буй җепләрне тыгызлап сугу юлы б-н әзерләнгән. 19 йөз уртасына кадәр өйдә тукылган тукымадан файдаланганнар. С.т. б-н, башлыча, хатын-кызлар шөгыльләнгән, сату өчен яки кулланучы кушуы буенча әзерләнгән тукымалар катлаулы алымнар б-н һәм бизәкләп тукылганнар. Фаразлар буенча, Казан һәм Зөя өязләрендә, Нурлат һ.б. волостьларда вак туку мануфактуралары эшләгән. Аларда туку станы ярдәмендә кул б-н комач тукымалар һәм баш яулыклары әзерләнгән.

Тукылган эшләнмәләр (сакланып калганнардан иң әүвәлгеләре 18 йөзнең 2 нче яртысына карый): сөлгеләр, япмалар, чаршаулар, ашъяулыклар, тастымаллар, түрләмәләр, кашагалар, каймалар, намазлыклар, борынгы киемнәр һ.б. — татар халкының көнкүрешендә гамәли, йола һәм бизәлеш функцияләрен башкарган: кәләш бирнәсенә кергән, туйларда, бәби ашларында, үлем-төшем көннәрендә, Җыеннарда, Сабан туйларында бүләк ителгән, алар б-н диварларны һәм бүлмә такталарын, тәрәзә аралыкларын бизәгәннәр, өйнең эчке өлешен бүлгәләгәннәр. С.т.ның төрки халыкларга хас иң борынгы төре — асалап сугу: бизәкләр төрле төстәге аркау җепләре б-н алдан билгеләнгән рәсем буенча, ике яклы тукыма хасил итеп түшәлә, төсле бизәкләр чигендә ачыклыклар барлыкка килә. Төксез йон келәмнәр ш.у. асалап сугу техникасында тукылган. Асалап сугылган 18–19 йөз уртасы келәмнәре башкару камиллеге һәм кара төстән башка барлык төсләр палитрасы диярлек файдаланылган (бер эшләнмәдә — 9–10 төс) нәфис бизәлеш б-н аерылып торалар. Орнаментта Урта Азия һәм Әзәрбайҗан келәмнәре, башкорт тукымалары б-н билгеле бер охшашлык бар. Ләкин татар эшләнмәләрендәге бизәкләр күптөслелек композицияләренең монументальлеге һәм сыгылмалылыгы, төп буйдагы эре, үрнәк каймалардагы тыныч төсмерле вак рәсемнәр каршы куелу б-н аерылып тора. С.т.ның катлаулы асалап сугу төре 19 йөз уртасыннан кулланылыштан әкренләп төшеп кала һәм бары тик келәмчелектә генә дәвам итә.

19 йөзнең 2 нче яртысыннан С.т.ның чүпләм, төсле чүпләм һәм түшәүле туку төрләре киң тарала. Чүпләм бизәк ике төстә була — нигездәге ак буй җепләрне кызыл яки зәңгәр, күк, яшел, сары төсләрдәге аркау җеп-





Сәнгати туку. Бизәкле сөлгеләр:
1. Асалап туку. 19 йөз ахыры;
2. Кыялап сугу. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы. ТР Милли музее;
3. Төсле чүпләм. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы. Барысы да – ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

ләр уздырып сугыла. Төсле чүпләм техникасында күп санлы аркау җепләр кулланыла, челтәрләр төрле төстә килеп чыга. Түшәүле тукуда (төсле чүпләм төре) буй яки аркау җепләрне озын атлатып бер якка гына түшәү хисабына бизәкләр эре була.

С.т.ның чүпләм төре зур өслекле эшләнмәләрне: пәрдә-кашагалар, ашъяулыклар, урын-җир җәймәләре, каймалы кашагалар, тастымаллар һәм сөлге башларын бизәгәндә кулланыла. Урал буе татарларының кайбер төркемнәрендә һәм керәшен татарларда чүпләмле һәм төсле чүпләмле бизәкләр, ш.у., хатын-кыз күлмәкләрен, алъяпкычлар, тастар читләрен бизәгәндә файдаланыла. Чүпләм төре бизәкләрен күрше рус, мари, удмурт халыкларындагы эшләнмәләрдә дә очратырга була. С.т.ның иң аз таралган техникасы — кыялап сугу, ул, башлыча, сөлге башларын бизәгәндә генә кулланыла. Бизәкләр 6–8 аркау җептән тукыла, аларны буй җепләр б-н бергә кушып сугудан фактуралы тукыма барлыкка килә. Аңа карлыгач койрыгы, ромбсыман һ.б. үрнәкләр хас.

Татар С.т.ының төп үзенчәлекләре тукыма эшләнмәләрдәге орнамент үрнәкләрендә һәм күптөслелегендә аеруча ачык чагыла. Туку осталары бизәкләрне кабатламаска тырышканнар, керенте өчпочмаклардан, ромблар, квадратлар, йолдызча, үсемлек үрнәкләреннән, свастикадан, X-, S- һәм 8-рәвешендәге стильләштерелгән чәчәк розеткаларыннан, күппочмакларның бер-берсенә үрелгән төрледән-төрле вариантларыннан файдаланганнар, буш калган урыннар вак бизәкчекләр б-н тулыландырылган. Кызыл, зәңгәр, күк, яшел, җирән бизәкләр, гадәттә, кызыл, куе кызыл, ак, алтынсу-сары фонга тукылган.

Өс киемнәре, көнкүреш кирәк-яраклары өчен тукыма әзерләгәндә, С.т.ның иң гади төре — алача кулланылган. Ул шакмаклы яки буйлы, ике яки өч төстә булган (кызыл, ак, күк, яшел, зәңгәр, сары төсләр б-н аралашып килгән). Буйлы алача хатын-кыз күлмәкләре тегү өчен файдаланылган. 19 йөз уртасыннан кулдан әзерләнгән тукымаларга ф-каларда эшләнгән тукыма алмашка килә. С.т. үзенең әһәмиятен югалта башлый. Ул Кама аръягының көнчыгышында һәм Башкортстанның шәһәрдән ерак урнашкан татар авылларында гына сакланып кала. Әле 20 йөз ахырында һәр авылда диярлек туку осталары асалап сугу техникасында эре бизәкле паласлар сукканнар һәм артык калган тукымалардан тар паласлар әзерләгәннәр. С.т. традицияләре Алексеев С.т. ф-касы җитештергән эшләнмәләрдә, «Туран» фонды сувенирларында (бизәкле сөлгеләр, кечкенә ашъяулыклар, тастымаллар һ.б.), Казан өйдә эшләүчеләр комб-тында яңадан үзенең үсешен тапты.

*Әд.:* Воробьёв Н.И., Бусыгин Е.П. Художественные промыслы Татарии в прошлом и настоящем. К., 1957; Валеев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995.

*Р.Р.Батыршин, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**СӘНГА́ТЬ БЕЛЕМЕ́**, сәнгать культурасын тулаем өйрәнүче иҗтимагый фәннәр (әдәбиятны, музыканы, театрны, архит-раны, кино сәнгатен өйрәнүче фәннәр һ.б.) комплексы; тар мәгънәдә сынлы сәнгать турындагы фән, сәнгать теориясеннән, тарихыннан, сәнгати тәнкыйтьтән гыйбарәт.

С. б.нең Татарстанда формалашуы Казан ун-ты галимнәренең эшчәнлеге б-н бәйле. С.б. гуманитар белемнәрнең бербөтен системасында мөһим элемент булып санала һәм ун-т галимнәре М.В.Л.Сторль, В.М.Перевощиков, И.Е.Срезневский лекцияләре һәм хезмәтләрендә, Туган телне сөючеләр җәмгыяте эшчәнлегендә әһәмиятле урын алып тора. Сәнгать теориясе һәм тарихы буенча беренче Казан басмалары арасында Казан ун-тының рәсем дәресе укытучысы, нәкышь академигы А.Н.*Ракович*, рәссам-педагог Р.А.Ступин китаплары бар. Казандагы сынлы сәнгатьнең һәм Казан рәссамнары иҗатының торышы турында беренче күзәтү Н.К.*Баженовка* карый. 19 йөзнең 2 нче яртысында тарих-филол. ф-ты составында нәфис сәнгать теориясе һәм тарихы каф. төзелгәч (Устав буенча 1863 тә оештырыла, 1886 да ачыла, 1918 дә бетерелә), Казан ун-ты Россиядә С.б. үсешенең үзәгенә әверелә. Кафедраның эшчәнлеге фәнни хезмәтләренең төп юнәлешләре эстетика тарихы һәм теориясе, борынгы Греция һәм Рим тарихы белеме, Византия тарихы белеме, башлангыч христиан сәнгате, Яңарыш чоры (Ренессанс) сәнгатенә багышланган күренекле галимнәр А.Н.Смирнов, Д.И.Нагуевский, В.К.*Мальмберг*, Д.В.*Айналов*, А.М.*Миронов* исемнәре б-н бәйле. Үзләренең фәнни хезмәтләрендә В.К.Мальмберг һәм Д.В.Айналов заманны узып фикер йөртәләр һәм Европада танылалар; алар, ун-тларга хас тематик курсларны яңа махсус курслар б-н киңәйтә төшеп, сәнгать белеме фәннәренең бай эчтәлекле өлешен күпкә яңарталар, ш.у. җирле борынгы ядкәрләр һәм сәнгать истәлекләрен өйрәнүгә нигез салалар, *Казан университетының нәфис сәнгать һәм борынгы истәлекләр музее* тупланмасын тулыландыруга булышлык итәләр. Кафедра *Казан нәфис сәнгать сөючеләр* җәмгыяте, Пушкин әдәбият һәм сәнгать җәмгыяте, *Казан сынлы сәнгать мәктәбе* эшчәнлекләрендә катализатор ролен уйный, музей белеменең теоретик нигезләре үсешенә, җирле сәнгать истәлекләрен өйрәнүгә, сәнгать педагогикасы һәм гүзәллек тәрбиясе, сәнгать тәнкыйте нигезләре барлыкка килүгә ярдәм итәләр. Б.П.Денике, П.М.Дульский, П.А.Радимов һ.б. шушы уку йортында белем ала. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында С.б. үсеше Б.П.Денике, П.М.Дульский, П.Е.Корнилов, А.Ф.Мантель, А.М.Миронов, В.П.Соколов хезмәтләрендә тарихи үткәнгә кагылышлы тикшеренүләр өстенлек итүе б-н үзенчәлекле (18–19 йөзләрдәге Казан губ. сәнгате). Л.О.Сиклер тарафыннан Шәһәр музееның (хәзерге ТР Милли музее) картиналар галереясы тупланмасы системага салына һәм аның каталогы төзелә. Христиан дине йолаларын һәм борынгы рус сәнгатен өйрәнүгә Казан епархиясенең Тарих-археология җәмгыяте һәм Казан руханилар академиясе профессорлары П.Е.Заринский, Е.А.Малов, И.М.Покровский, К.В.Харлампович һ.б. лаеклы өлеш кертәләр. Сәнгать белеменә кагылышлы мәкаләләр, сәнгать күргәзмәләренә багышланган рецензияләр «Камско-Волжская речь», «Волжский вестник», «Казанский телеграф», «Вечерняя почта» һ.б. г-таларда, «Известия общества археологии, истории и этнографии

Казанского университета», «Учёные записки Казанского университета», «Жизнь», «Волжские дали», «Волжское утро» ж-лларында даими басылып килә. Казан сәнгать тарихчылары язмалары ш.у. үзәк ж-ллар «Аполлон», «Старые годы», «Среди коллекционеров» битләрендә дөнья күрә. А.Ф.Мантельнең наширлек һәм сәнгать-тәнкыйть эшчәнлегендә үзәк урынны заманча сәнгать һәм яңа агымнар мәсьәләләре: импрессионизм, символизм, футуризм алып тора. А.Ф.Мантельнең сәнгать юнәлешендәге «На рассвете» нәшрияты (1912 дә ачыла) «На рассвете», «Зилант», «Неофутуризм» әдәбият-сәнгать альманахлары һәм монографияләр (мәс., Н.К.Рерихка, Д.И.Митрохинга багышланган) бастырып чыгара.

19 йөздә татар һөнәрчелек сәнгате һәм наширлек өлкәсендә «Зәргәрчелек һәм агач эше һөнәрләре турында» брошюрасы һәм затлы металлдан эшләнгән әйберләр эшкәрткәндә кулланылган электролиз ярдәмендә никельләү технологиясе буенча «Сәнаигъ галвания» («Гальваника сәнгате», 1900) уку ярдәмлеге авторы К.*Насыйри* тикшеренүләре мәгълүм була. Ул Татар китабын бастыруга кагылышлы мәкаләләр авторы да. Әлеге язмаларында К.Насыйри бизәлеш сәнгатенә зур игътибар бирә («1883 елга татар календаре»). 20 йөз башы татар вакытлы матбугатында татарлар арасында сынлы сәнгатьтә Европа формаларын үстерү кирәклеге, ш.у. каллиграфия һәм тулаем мөселман сәнгате эстетикасы турында язмалар еш дөнья күрә (Г.Тукай, Г.Камал, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Һ.Атласи һ.б.). 1915 тә Казанда чыгучы «Аң» ж-лына кушымта сыйфатында беренче тапкыр Европа классиклары әсәрләре б-н «Сынлы сәнгать альбомы» дөнья күрә (Г.Ибраһимовның кереш мәкаләсе).

20 йөзнең 1 нче яртысы, сынлы сәнгать, музей белеме, эстетик тәрбия, сәнгать тәнкыйтенең теоретик базасы буларак, С.б.нең интенсив формалашу чоры була. С.б. проблемалары яңа учреждениеләр: Татарстан Мәгариф халык комис-тында Борынгы әйберләр һәм сәнгать истәлекләрен саклау бүлеге, Татарстан Мәгариф халык комис-тының Академия үзәге, Татарларны өйрәнү белеме фәнни җәмгыяте, Татар мәдәнияте йорты, Татарстан икътисад фәнни-тикшеренү ин-тының сәнгать кабинеты, ТАССР Үзәк музееның сәнгать бүлеге, Казан архит-ра-сәнгать остаханәләре, Шәрекъ академиясе һ.б. эшчәнлегендә гамәли тормышка ашырыла. П.М.Дульский, П.Е.Корнилов, А.М.Миронов, Б.П.Денике, К.И.Сотонин, ш.у. татар сәнгате белгечләре М.З.Кәримов, С.М.Ишморатова хезмәтләре Мәскәү, Ленинград, Казан шәһәрләрендәге хәзерге рәссамнар иҗаты (күргәзмәләре ТАССР Үзәк музеенда үткәрелә), татар халык сәнгате һәм хаттатчылык, сәнгать һөнәрчелегенең традицион төрләре, ш.у. Казан, Болгар, Зөя, Алабугадагы архит-ра-сәнгать истәлекләре кергән тематик тикшеренүләренең киңәюе б-н характерлана. Татарларның сәнгать мирасын (Урта гасырлар мәдәнияте, традицион бизәлеш һәм гамәли сәнгатен, архит-расын, каллиграфиясен һ.б.) сәнгать белгечләре (П.М.Дульский, Е.П.Корнилов, Б.П.Денике), тарихчылар, археологлар һәм этнографлар (Б.Ф.Адлер, Е.Э.Адольф, Гали Рәхим, Ф.В.Баллод, А.С.Башкиров, Н.И.Воробьёв, Н.Ф.Высоцкий, А.А.Девишев, Н.Ф.Калинин, В.Ф.Смолин) тарафыннан планлы рәвештә өйрәнү 1920 елларның 2 нче яртысыннан соң гына башлана. Сәнгать тәнкыйте — төрле сәнгать юнәлешләренең кискен бәхәсле көрәше (ТатАХРР, ТатЛЕФ, Сулф), ә 1930 еллар уртасыннан соц. реализм теориясе кысаларында тоташ идеологияләштерү б-н характерлана. Сәнгать белеменә караган язмалар респ-каның вакытлы басмаларында: «Казанский музейный вестник», «Казанский библиофил», «Листок литературы и искусства» («Известия ТатЦИК» кушымтасы), «Записки Тетюшского музея» һ.б.да дөнья күрә. Басма эшчәнлек, ш.и. А.В.Луначарский исем. *полиграфия мәктәбе* (ТАССР Үзәк музееның сәнгать күргәзмәләре каталоглары), Казан архит-ра-сәнгать остаханәләре (мәкаләләр җыентыгы үткәндәге һәм хәзерге заман осталары И.И.Шишкин, Н.И.Фешин, К.К.Чеботарёв, А.Г.Платунова, Ф.П.Гаврилов һ.б.ның иҗатына багышланган монографик тикшеренүләр) тарафыннан да тормышка ашырыла. Ләкин 1930–40 елларда сәнгать белеме фикере тагын да ныграк идеологияләштерелә.

1940–50 еллар ахырында рәссам П.Т.Сперанскийның «Татар халык орнаменты» (П.М.Дульскийның кереш мәкаләсе), Мәскәү сәнгать белгече Н.В.Черкасованың «Совет Татарстаны сынлы сәнгате» (1957) альбомнары, С.М.Ишморатова һәм А.Мирлинның ТАССР Дәүләт музее сәнгать тупланмасының беренче каталогы (1956), ш.у. «Совет әдәбияты» ж-лында С.Ш.Ишморатова, Б.И.*Урманче* һ.б.ның шул заман рәссамнарының иҗатларын яктырткан мәкаләләре басылып чыга. 1960 еллар башыннан Казанда җирле проф. кадрлардан: ТАССР Сынлы сәнгать музее хезмәткәрләреннән (Я.Х.Вайсфельд, Д.К.Вәлиева, Г.А.Могильникова, А.И.Новицкий, Н.З.Саттарова, А.Б.*Файнберг* һ.б.), Казан сәнгать уч-щесе һәм гуманитар профильле югары уку йортлары укытучыларыннан (Л.Я.*Елькович*, А.Д.Сысоев һ.б.) сәнгать белеме мәктәбе формалаша башлый. Аларның эшчәнлеге, башлыча, респ-каның совет чоры сынлы сәнгатен, Казан губернасы сәнгатен өйрәнү һәм пропагандалау б-н бәйле. Л.Я.Ельковичның «Чаян» ж-лының сатирик графикасына, рәссамнарына, сынлы сәнгатькә («Художники Татарии», Л., 1965) багышланган күргәзмә каталоглары, альбомнары, А.Б.Файнбергның алга таба рәссамнар иҗаты, станлы нәкышь, графика һәм скульптура үсеше, Рәссамнар берлеге эшчәнлеге турында, ш.и. «Искусство», «Художник» үзәк басмаларында басылган мәкаләләрдән, «Татарстан рәссамнары» (Л., 1983) монографиясендә гомумиләштерелгән хезмәтләре, Г.А.Могильникованың «Сынлы сәнгать музее экспозициясе буенча күрсәткеч»е (1970) һ.б. басыла. 1968 дә СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында татар сынлы һәм бизәлеш сәнгатенең тарихы һәм теориясе б-н планлы рәвештә шөгыльләнүче сәнгать белеме бүлеге оештырыла. Анда бүлек оешуның беренче көннәреннән татар С.б.нә нигез салучыларның берсе — Идел буенда беренче сәнгать белеме д-ры Ф.Х.*Вәлиев* эшли башлый. Аның хезмәтләре (7 китабы басыла) — татар халык орнаменты, архит-расы һәм гамәли-бизәлеш сәнгате, Урта Идел буеның урта гасырлар сәнгатенең тарихы һәм теориясе өлкәсендә фундаменталь тикшеренүләр. Ф.Х.Вәлиев, фәнни һәм туплау эшчәнлеге б-н актив шөгыльләнү нәтиҗәсендә бергә *халык нәфис кәсепчелеген* яңадан торгызуга, сувенирлар җитештерүгә булышлык итә, ТАССР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда татар гамәли-бизәлеш сәнгатенең музей тупланмаларына нигез сала. 1970 еллардан башлап, респ-ка рәссамнары иҗатында күзәтелгән соц. реализмның идея агымы объекты буларак, сынлы сәнгать Мәскәү сәнгать белгече С.М.*Червоннаяның* максатчан өйрәнү өлкәсенә әйләнә («Искусство Советской Татарии», М., 1978). Ул — Казанда басылган бер исемдәге ике биографик белешмә («Художники Советской Татарии», 1975 һәм 1984), борынгы заманнардан респ-каның сәнгать тарихына һәм, башлыча, Казан галимнәренең тикшеренүләрен гомумиләштергән хезмәт авторы («Искусство Татарии», М., 1987). 1980 еллар башыннан С.б. үсеше җирле фәннәр академиясе, музей эшләре һәм сәнгать тәнкыйте кысаларында тормышка аша. Беренче коллектив хезмәтләр (фәнни мәкаләләр җыентыклары) барлыкка килә, музей хезмәткәрләренең конференцияләре оештырыла, күргәзмә эшчәнлеге киң җәелдерелә, җирле («Казан утлары», «Татарстан», «Идел» һ.б.) һәм үзәк («Художник», «Искусство», «Декоративное искусство») басмаларда пропагандалана. С.б. өлкәсендә махсуслашу тикшеренүләр тематикасын баета, Татарстан сәнгате тарихын һәм теориясен өйрәнү даими тирәнәя бара: монументаль-гамәли сәнгать (Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова), 10–12 йөзләрдәге Идел буе болгарлары сәнгате (Д.К.Вәлиева), 19 йөздә — 20 йөзнең 1 нче чирегендә Урта Идел буенда сәнгать тормышы тарихы (Е.П.Ключевская), чигү һәм күн каю сәнгате буенча китаплар (Ф.Ф.Гулова), Татарстан рәссамнары Х.Г.Якупов, Л.Г.Фәттахов, Б.И.Урманче турында китаплар һәм альбомнар, «Совет Татарстаны сәнгате. Халык рәссамнары» буклетлар җыентыгы басыла, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музееның күргәзмәләр каталоглары, сәнгать тупланмалары басмалары дөнья күрә (А.И.Новицкий, В.Н.Разумейченко, Р.Г.Шаһиева, В.А.Цой, Е.П.Ключевская һ.б.). 1990 елларның 2 нче яртысыннан С.б., академик сәнгать буларак, ТР ФА-нең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты, Тарих ин-ты, Татар энциклопедиясе ин-ты кысаларында үсә. Татарстан сәнгатен өйрәнү методологиясе проблемалары киңәя һәм тирәнәя, тикшеренүләр комплекслы төс ала, С.б. тарих, этнография, археология, социология, семиотика һ.б. фәннәр берләшкән урында тормышка ашырыла. Татарстанның гамәли сәнгате (Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова), татар шәмаилләре сәнгате (Р.И.Шәмсутов), респ-каның яңа сәнәгать шәһәрләрендә сынлы сәнгатьне

үстерү (Р.Р.Солтанова), Алтын Урда чоры Идел болгарлары сәнгате (Д.К.Вәлиева) һ.б. буенча гомумиләштерелгән хезмәтләр барлыкка килә. Сынлы сәнгатьтәге тикшеренүләр С.б. кысаларыннан чыга, эстетика һәм философия (Б.М.Галиев, К.Т.Гыйззәтов, Й.Г.Нигъмәтуллина, Е.В.Синцов һ.б.), этнография (М.К.Завьялова, Р.Г.Мөхәммәдова, С.В.Суслова, Ф.Ш.Сафина һ.б.) хезмәтләренә кушылалар, гуманитар профильле югары уку йортларында укыту программаларының бер өлешенә әйләнәләр. Казан мәдәният һәм сәнгать ун-ты, Казан пед. ун-ты, Казан ун-ты, Казан сәнгать уч-щесе һ.б. хәзерге вакытта ярдәмче тармак рәвешендә сәнгать тарихы һәм теориясе өлкәсендә мәгариф үзәкләре булып торалар (респ-кадагы югары уку йортларында сәнгать тарихы һәм теориясе укытылмый). Дизайн тарихы һәм теориясе мәсьәләләре Казан архит-ра төзелеш академиясенең дизайн кафедрасында тикшерелә. «Сәнгать-фән-техника» фәнара өлкәләрдә яңа аудио-, видеотехнологияләрне өйрәнү б-н «Прометей» тәҗрибә-эстетика Фәнни-тикшеренү ин-ты шөгыльләнә. Сынлы һәм бизәлеш сәнгатен пропагандалауда музейлар һәм күргәзмәләр эшчәнлеге күпкә киңәя (к. *Музейлар*). Яшел Үзән шәһәрендә, Яңа Чишмә р-нының Зиректе авылында халык иҗаты һәм көнкүреш музейлары, Б.Урманче, И.Зарипов, Х.Якупов, З.Басыйров һ.б.ның музейлары оештырыла. «Казан Кремле» Дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгында сәнгать әсәрләренең зур күргәзмә мәйданчыкларына әверелгән «Эрмитаж-Казан» үзәге» (2005), «Хәзинә» милли сәнгать галереясы (2005), «Манеж» күргәзмә залы (2009), Ислам мәдәнияте тарихы музее (2006) эшли башлый. 2013 тә Казанда «Смена» заманча мәдәният үзәгендә Хәзерге заман сәнгать галереясы (хосусый) ачыла; 2016 да ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее каршында Рус музееның мәдәният-күргәзмә үзәге оештырыла. Сәнгать белеме өлкәсендә югары хәзерлекле яңа яшь кадрлар (фән кандидатлары) әзерләнә (О.Л.Улемнова, Г.Р.Фәйзрахманова, Л.Донина, Г.Тулузакова һ.б.). Респ-каның сәнгать тормышы, заманча иҗат процессы һәм сынлы сәнгать үсеше «Казан», «Татарстан», «Идел», «Сөембикә» һ.б. ж-ллар кебек вакытлы матбугат басмалары сәхифәләрендә яктыртыла. ТР Рәссамнар берлеге составында респ-каның әйдәп баручы сәнгать белгечләрен берләштергән тәнкыйть секциясе эшли. С.б. өлкәсендәге тикшеренүләрне координацияләү 1992–2009 да ТР ФА каршында оештырылган Сәнгать белеме һәм эстетика фәнни советы кысаларында тормышка ашырыла (2009 га кадәр рәисе — Б.М.Галиев).

*Әд.:* Ключевская Е.П. Из истории искусствоведения в Татарстане // Татарстан. 1996. № 10; Кто есть кто в науке об искусстве (Республика Татарстан): Справ. К., 1998.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, Е.П.Ключевская.*

**СӘПӘ́Й** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 7 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Вәрҗәде елгасы буенда. 2010 елда 661 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1748 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Чытырлы исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәктәп, земство хастаханәсе (бина 1912–14 елларда төзелә; архит-ра истәлеге) була; дүшәмбе базары, ярминкә эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3172 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Азнакай волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1822 дә — 186 ир-ат; 1859 да — 878, 1889 да — 1183, 1897 дә — 1360, 1910 да — 1545, 1920 дә — 1698, 1926 да — 1267, 1938 дә — 1209, 1949 да — 904, 1958 дә — 1003, 1970 тә — 875, 1979 да — 722, 1989 да — 555, 2002 дә — 661 кеше.


**СӘР-БОЛА́К** (Серболак) елгасы, Көнбатыш Кама алдында. Сумка елгасы бассейнына карый. Озынлыгы 11,5 *км*, бассейнының мәйданы 67,1 $км^2$. Яшел Үзән р-ны терр-ясеннән ага. С.-Б. бассейнының шактый өлеше Идел-Кама саклаулыгының Раифа участогында. Елга башы урман массивында, Кызыл Октябрь урманчылыгы посёлогыннан 5 *км* төньяк-көнбатыштарак, Карабалык һәм Кәрәкә күлләре, Осиново, Коры һәм Казан сазлыклары аша ага, Раифа посёлогы янында Раифа күленә коя. Елга башының абс. биеклеге 120 *м*, тамагыныкы — 70 *м*. Су җыелу мәйданы катнаш урман б-н капланган аз гына авыш тигезлектән гыйбарәт, урманлылыгы 100%. Үзәне яхшы эшкәртелгән, туры, киң һәм тар участокларның чиратлашуы күзәтелә, ара-тирә ерым һәм сызалар урын алган. С.-Б.ның 3 *км* озынлыктагы 1 кушылдыгы бар — Осиново сазлыгыннан көнбатыштарак коючы Кече Сәр-Болак инеше (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,21 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 $л/с·км^2$. Кар эрегән вакытта елганың биеклеге нык арта һәм ул якын-тирә урман участокларын су астында калдырып, ярларыннан чыга. Бассейнда язгы ташу агымы катламы 20 *мм*. Җәен агым катламы бик түбән. Елганың югары агымы көчсез, әмма күп санлы грунт чыганаклары исәбенә (елга башыннан Осиново сазлыклыгына кадәр) даими. Җәен С.-Б. урта һәм түбән агымында кибә, озакка сузылган җәйге һәм көзге яңгырлардан соң гына элеккеге хәленә кайта. Түбән агымында сазлыклар күп, аларда урыны-урыны б-н елганың юлы югала; бу урыннарда елганың даими агымы язын гына күзәтелә, коры вакытта су бары тик елганың тирән урыннарында гына кала. Раифа күленә койган урында суының уртача күпьеллык чыгымы: суының иң аз вакытында 0,7 $м^3/с$, язын 3,9 $м^3/с$. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан артык.

*Әд.:* Тайсин А.С. Озёра Приказанского района, их современные природные антропогенные изменения. К., 2006.

**СӘРӘМӘ́К** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Лубян елгасының (Вятка елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 15,8 *км*, ТР чикләрендә — 1 *км*. Бассейнының мәйданы 141 $км^2$. Можга калкулыгы буйлап ага. Елга башы һәм шактый өлеше Удмурт Респ-касы терр-ясендә, тамагы Кукмара р-ны Лубян авылыннан 1 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 67 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 45%. С.нең 1 дән 3,9 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,19 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 3–5 $л/с·км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 110 *мм*, ташу агымы катламы 74 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,14 $м^3/с$. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**СӘРӘПӘЛЕ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Дала Зәе елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 18,9 *км*, бассейнының мәйданы 91,2 $км^2$. Зәй р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Нератовка авылыннан 1,5 *км* төньяк-көнбатыштарак. Поручик авылыннан 3 *км* көнчыгыштарак, 119 нчы *км* тимер юл станциясе янында Зәй сусаклагычына коя. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 72 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 45%. С.нең 0,4 тән 6,5 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 $км/км^2$. Туенуы катнаш, өчтән ике өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 $л/с·км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 118 *мм*, ташу агымы катламы 76 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,131 $м^3/с$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

**СӘРӘПӘЛЕ́** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 10 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сәрәпәле елгасы буенда. 2010 елда 194 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. С. исемен 1710–11 дән йөртә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Сәрәпәле буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, вак һөнәрчелек б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 19 йөз ахы-



Н.С. Сәрвәров.

рында миссионерлык мәктәбе ачыла. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1230 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 325, 1897 дә — 748, 1913 тә — 901, 1920 дә — 593, 1926 да — 1070, 1938 дә — 833, 1949 да — 663, 1958 дә — 541, 1970 тә — 549, 1979 да — 320, 1989 да — 197, 2002 дә — 181 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**СӘРӘТӘ́**, к. *Су балтырганы.*

**СӘРВӘ́РОВ** Наил Сәрвәр улы (10.11.1946, Чаллы ш.), балет артисты, педагог, ТАССРның халык артисты (1987). 1968 елда — Пермь хореография уч-щесен (педагог Ю.Плахт), 1990 да Дәүләт театр сәнгате ин-тын (Мәскәү) тәмамлый. 1969–90 да Татар опера һәм балет театры солисты. 1990 нан — Башкорт опера һәм балет театры, 1991 дән — М.Глинка исем. Чиләбе опера һәм балет театры, 1993 тән А.Пушкин исем. Түбән Новгород опера һәм балет театры педагог-репетиторы. 1994–2000 дә һәм 2003 тән Уфа хореография уч-щесе һәм бер үк вакытта Башкортстан Респ-касының Ф.Гаскәров исем. Дәүләт акад. халык биюләре ансамблендә педагог. 2000–03 тә Мисыр балет академиясендә (Каһирә). 2005 тән Башкорт пед. ун-тының хореография кафедрасында укыта.



Н.С. С ә р в ә р о в  Былтыр ролендә («Шүрәле», Ф.Яруллин). 1970.

Ганс, Конрад («Жизель», «Корсар», А.Адан), Меджа («Сильфида», Х.Левенсхольд), Ротбарт, фея Карабос («Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл», П.Чайковский), Тореро («Дон Кихот», Л.Минкус), Тореадор («Кармен-сюита», Ж.Бизе-Р.Щедрин), Былтыр («Шүрәле», Ф.Яруллин) партияләрен башкара.

**СӘРВИ́**, а к а ц и я (Caragana), кузаклылар семьялыгыннан яфрак коючан куаклар яки зур булмаган агачлар ыругы. 80 гә якын төре билгеле, Европа һәм Азиядә таралганнар. ТР да 2 төре бар: агачсыман С. яки сары акация (C. arborescens) торак пунктларны яшелләндерү, урман ышыклау полосалары (башка куакчыл үсемлекләр б-н әрәмәлекләр хасил итә) булдыру өчен үстерелә. Куакчыл С. (C. frutex) Кама аръягында очрый, далаланган тау битләрендә үсә, ара-тирә культуралаштырыла. 0,5–5 *м* биеклектәге куаклар. Куакчыл С. кара-көрән яки сары, агачсыман С. соры-яшел кабыклы. Яфраклары чиратлашкан, катлаулы, парлы-каурыйсыман, төпчек яфраклары чәнечкеле. Чәчәкләре сары, 2–5 яки ялгыз чәчәкле бәйләмдә. Җимеше — цилиндрсыман кузак. Май–июньдә чәчәк аталар. Җимешләре июль–августта өлгерә. Яфракларында целлюлоза, С витамины, каротин; чәчәкләрендә — флавоноид; орлыкларында углевод, дуплау матдәләре, май бар. Халык медицинасында яфрак һәм чәчәкләреннән ясалган төнәтмә баш авыртканда, атеросклероз, бавыр авыруларыннан кулланыла. Яфрак төнәтмәсе — бактерияләргә каршы көрәшү чарасы. Үзагачы вак эшләнмәләр, кыршау, кәрзиннәр ясау өчен яраклы. Баллы үсемлек. Тау битләрен ныгыту өчен файдаланалар. Орлыклары кошлар өчен азык булып тора.

*Әд.:* Б а к и н О.В., Р о г о в а Т.В., С и т н и к о в А.П. Сосудистые растения Татарстана. К., 2000.

**СӘРДӘ́** (Aegopodium), чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 7 төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади С. (A.podagraria) барлык районнарда очрый. Катнаш һәм киң яфраклы урманнарда, куаклар арасында, урман буйларында үсә. 60–100 *см* биеклектәге үсемлек. Тамыр системасы озын, шуышма. Сабагы туры. Тамыр яны һәм түбән сабак яфраклары озын саплар-да урнашкан, икешәр-өчәрле, зурлар, өскеләре — кечкенә, өчәрле, кыска саплы. Чәчәкләре ак, вак, күп тармаклы чатыр чәчәк төркеменә җыйналган. Җимешләре кара-көрән озынча һәм ян-яктан аз гына кысылган салпы җимешлек. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Үләнендә эфир мае, азотлы кушылмалар, С витамины, флавоноидлар һәм микроэлементлар бар. Халык медицинасында аның төнәтмәсе подагра һәм ревматизм вакытында кулланыла. Яшь яфраклары ашарга яраклы. Терлек азыгы. Баллы үсемлекләр.

**СӘРДӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Шушма елгасының (Вятка елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 21 *км*, ТР чикләрендә — 14 *км*. Бассейнының мәйданы 162,4 $км^2$. Елга башы һәм югары агымы Мари Респ-касында, тамагы Арча р-ны Апаз авылында. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 99 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 22%. С.нең 1 дән 11,9 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар, аеруча зурлары: Мамсинер (11,9 *км*) — сул, Шука (8,3 *км*) — уң кушылдык. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 $км/км^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 $л/с·км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 136 *мм*, ташу агымы катламы 120 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,09 $м^3/с$. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**СӘРДӘ́** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 10 *км* төньяктарак, Мишә елгасының (Мишәнең (Мёша) бассейны) сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 230 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. Рус чыганакларында 1678 дән По речке Сарде исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.дә мәчет, мәктәп, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1206,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Бөкмеш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 80 ир-ат; 1859 да — 496, 1897 дә — 656, 1908 дә — 715, 1920 дә — 725, 1926 да — 670, 1938 дә — 562, 1949 да — 430, 1970 тә — 324, 1979 да — 292, 1989 да — 225, 2002 дә — 236 кеше.

**СӘРДӘБА́Ш** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 48 *км* төньяктарак, Мари Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 298 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында По речке Сарде исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.та мәчет, мәктәп, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1415,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Арбор волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1905 тә — 771, 1920 дә — 1048, 1926 да — 830, 1938 дә — 676,

1949 да — 524, 1958 дә — 528, 1970 тә — 474, 1979 да — 378, 1989 да — 297, 2002 дә — 287 кеше.

**СӘРДӘЛЕ́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 33 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чаж елгасы буенда. 2010 елда 9 кеше (руслар) яши. 19 йөз ахырында Агарёвка авылыннан (хәзер Удмурт Респ-касының Кече Пурга р-нында) күченүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Починок Серделинский исеме б-н дә билгеле. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Сарсак-Умга волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1897 дә — 97, 1905 тә — 142, 1920 дә — 163, 1926 да — 187, 1938 дә — 195, 1958 дә — 81, 1970 тә — 65, 1989 да — 20, 2002 дә — 12 кеше.

**СӘРДӘНӘ́**, к а л ф а к ч ә ч ә к (Corydalis), мәк чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 320 гә якын төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Тыгыз С. (C. solida) бөтен җирдә, урта С. (C. intermedia) — Кама алдында, Маршалл С.се (C. marschalliana) Идел алдында очрый. Киң яфраклы һәм катнаш урманнарда үсәләр. 10–25 *см* биеклектәге үсемлекләр. Тамырлары бүлбесыман. Сабаклары туры. Яфраклары чиратлашкан, икешәр, өчәр теленмәле. Чәчәкләре зур түгел, чыгынтылы сары, аксыл, алсу төстә, чук чәчәк төркемендә. Җимеше — кузаксыман тартмачык. Орлыклары ялтыравыклы, кара, итчел үсентеле. Җимешләре июньдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Баллы, декоратив үсемлекләр. Маршалл С.се ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**СӘРДӘҮ́Ч** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Оштырма елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 39 кеше (татарлар) яши. Халкы кырчылык б-н шөгыльләнә. 1719 га кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Живут Себе Усадом исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н көн күрә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 356,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 24 ир-ат; 1859 да — 124, 1897 дә — 228, 1908 дә — 246, 1920 дә — 261, 1926 да — 264, 1938 дә — 203, 1949 да — 196, 1958 дә — 160, 1970 тә — 132, 1979 да — 97, 1989 да — 64, 2002 дә — 47 кеше.

**СӘРДӘҮ́Ч** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 50 *км* көнчыгыштарак, Удмурт Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 56 кеше (татарлар, руслар) яши. 1930 елларда нигез салына. Торак пункт буларак 1960 ның 22 июнендә теркәлә. Оештырылган көненнән Тәкәнеш р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1938 дә — 160, 1970 тә — 198, 1979 да — 92, 1989 да — 70, 2002 дә — 60 кеше.

**СӘРДЕ́К** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 35 *км* төньяктарак, Кугубор елгасы буенда. 2010 елда 196 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.тә су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1647,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Шода волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1905 тә — 827, 1920 дә — 997, 1926 да — 978, 1938 дә — 467, 1949 да — 373, 1958 дә — 354, 1970 тә — 275, 1979 да — 238, 1989 да — 204, 2002 дә — 205 кеше.

**СӘРДЕКБА́Ш** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 28 *км* төньяк-көнбатыштарак, Борбаш елгасы буенда. 2010 елда 247 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, яшелчәчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1638 дән Урта Сәртек исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1039,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Сәрдекбаш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 299, 1884 тә — 391, 1905 тә — 548, 1920 дә — 676, 1926 да — 623, 1938 дә — 573, 1949 да — 381, 1958 дә — 261, 1970 тә — 265, 1979 да — 274, 1989 да — 269, 2002 дә — 269 кеше.

**СӘРТЕ́К** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 39 *км* көнбатыштарак, Шыя елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 161 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, китапханә. 1619 дан рус чыганакларында Пустошь Сартик исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Салтыковка буларак мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1030,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кабык Күпер волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 69 ир-ат; 1859 да — 444, 1897 дә — 757, 1908 дә — 840, 1920 дә — 891, 1926 да — 746, 1949 да — 659, 1958 дә — 576, 1970 тә — 562, 1979 да — 452, 1989 да — 260, 2002 дә — 191 кеше.

**СӘҮДӘ́**, икътисадның товарлар әйләнешен, аларның җитештерү өлкәсеннән куллану өлкәсенә хәрәкәтен тәэмин итүче тармагы. Эчке (күмәртәле һәм ваклап сату) һәм тышкы, даими һәм вакытлыча С.гә бүленә. Татарстанда С. өлешенә респ-ка тулай төбәк продуктының 13% ы, РФнең ваклап сату С.се әйләнешенең 2,6% ы, күмәртәле С. әйләнешенең 1,2% ы туры килә (2007). Ваклап сату С.сенең барлык пр-тиеләренең һәм объектларының 99% ы (4 меңнән артык) дәүләти булмаган милкенә карый.

103 базарда (азык-төлек, әйберләр, катнаш; 28 мең сәүдә урыны) товарларның 8% ы сатыла (к. *Базар*). С.дә 296 меңнән артык кеше (икътисади актив халыкның 15,5% ы) мәшгуль. Шәһәрләрдә ваклап сату С.се әйләнешенең 92% ы, ш.и. Казанда — 58% ы, Чаллыда 18% ы формалаша.

Хәзерге Татарстан терр-ясендә С.нең иң борынгы формасы турыдан-туры товар алмашудан гыйбарәт була. Акча барлыкка килү б-н, ваклап сату һәм күмәртәле С. үсә башлый. 8–9 йөзләрдә С.не — җитештерүчеләр үзләре, тышкы С.не сәүдәгәрләр алып бара. 8 йөздән Төньяк һәм Үзәк Европа илләрен Шәрекъ б-н тоташтырган Бөек Идел сәүдә юлы системасында Идел буе Болгар дәүләте мөһим буынга әверелә. Эчке базарда хуҗалык һәм көнкүреш ихтыяҗларында җитештерелгән һөнәрчелек эшләнмәләре (сукалар, китмәннәр, ат дирбиясе, балчык савыт-саба һ.б.) б-н сәүдә итәләр. С. тормышы Болгарда, Биләрдә, Суарда, Ашлыда һ.б. шәһәрләрдә туплана, аларда даими рәвештә базарлар эшли һәм ел саен ярминкәләр уздырыла. Ага-Базар С. һөнәрчелек үзәге һәм пристань буларак танылa. Читкә, башлыча, мехлар, зәркән бизәмәләр (күбесенчә көмеш бизәнү әйберләре), тимерчелек, сөяк һәм тире эшкәртү һөнәрләре эшләнмәләре чыгарыла. Читтән күбесенчә зиннәтле әйберләр (алтын савыт-саба, тау бәллүре, киҗе-мамык һәм ефәк тукымалар, бизәмәләр, келәмнәр) һәм корал (туры кылычлар, хәнҗәрләр һ.б.) кертелә.

Казан ханлыгында да (1445–1552) С. мөһим урын били. 15 йөздә Казан эре сату базарына әверелә. Җирле һәм чит илләрдән килгән сәүдәгәрләр читкә мехлар, бал, икмәк, күн һ.б. эшләнмәләр чыгаралар, читтән җиләк-җимеш, тукымалар, кыйммәтле әйберләр, корал кертелә. Төп С. партнёрлары Мәскәү дәүләте һәм рус кенәзлекләре, Кавказ, Төркия, татар ханлыклары була. Тышкы икътисади операцияләрне гамәлгә ашыру өчен, ел саен Иделдәге «*Маркиз» утравында* халыкара ярминкә (13 йөздән мәгълүм, 1524 елга кадәр эшли) ачыла, Казанның *Ташаяк* ярминкәсе популярлык казана.

1552 дә Казан ханлыгын Иван IV (Грозный) яулаганнан соң, Рус дәүләте тарафыннан татарлар өчен чикләүләр кертелә: алар ирексезләп шәһәрләрдән чыгарыла, шәһәрләрдә С. рөхсәт ителми (1685 кә кадәр), рус булмаган халыкка «тыелган» товарлар (кораллар, сугыш кирәк-яраклары, металл хезмәт кораллары, корал ясарга яраклы металлар һ.б.) сату тыела. Төбәктә С. озак вакытлар төшенкелек кичерә. Казанның сәүдә әһәмияте 17 йөз ахырында гына тергезелә. Шәһәр Бөек Идел сәүдә юлында эре транзит пунктына әверелә, төбәктә эчке С. дә җанлана. 1860 ка 5448 сәүдәгәр (ш.и. гаиләләрне кертеп) исәпләнә. Күпсанлы базарлар, 9 меңнән артык сәүдә пр-тиеләре (кибетләр, лавкалар һ.б.) эшли, шуларның 40% ы — сәүдәгәрләр, 55% ы — мещаннар, 5% ы крәстияннәр милкендә була. С. әйләнеше 20 млн. сумнан артып, Россия С. әйләнешенең 3% ы чамасын тәшкил итә (1865).

19 йөзнең 2 нче яртысында С., башлыча, стационар сату челтәре аша гамәлгә ашырыла. Эчке базарда продукциянең шактый өлеше крепостнойлык хокукы бетерелгәч һәр җирдә ишәйгән ярминкәләрдә сатыла. Универсаль ярминкәләр өстенлек итә. Эре һәм уртача зурлыктагы ярминкәләр аермачык рәвештә махсуслашалар: Кәрван ярминкәсендә (Лаеш ш. янында) — тимер, Урман ярминкәсендә (Козьмодемьянск ш. тирәсендә) — төзелеш агачы, Язгы ярминкәдә (Казанда) — савыт-саба, чәй, Минзәлә ярминкәсендә (ул вакытта Уфа губернасына керә) — атлар (елга 1400 башка кадәр), чәй, Алабуга ярминкәсендә (Вятка губ.) пыяла һәм фарфор савыт-саба, мануфактура, кустарь эшләнмәләр б-н С. итәләр. Капитализм үсешенә бәйле рәвештә эчке С.дә ярминкәләрнең роле сизелерлек кими. Күмәртәле С. ярминкәләрдән биржаларга күчә (1866 да — Казан, 1910 да Чистай биржалары оештырыла). Коммерциядә өстенлекле позицияләрне күмәртәләп эш итүчеләр били: барлык сәүдә оешмаларының 1% тан кимрәк өлешен тәшкил иткән эре пр-тиеләргә товар әйләнешенең өчтән бере туры килә. Аеруча зур капиталлар икмәк, он б-н С. итүгә салына (товар әйләнешенең 40% ына кадәр), 2 нче урынны чәй һәм шикәр С.се били (14%). Мануфактура-галантерея һәм бакалея С.сенә тиңдәшле рәвештә 11% һәм 6% туры килә. Төбәк товар әйләнешендә икмәк С.сенең чагыштырмача өлеше 30% ка азая, чәй сәүдәгәрләрнең операцияләре кими, мануфактура С.сенең өлеше, киресенчә, 17% ка кадәр арта. Чимал (эшкәртелмәгән күн, йон, кыл, терлек мае, йомырка) сату элеккечә үк төбәк С.сенең мөһим өлеше булып кала.

1872–1916 да теркәлгән 300 сәүдә йорты һәм АҖнең 28% ы татар эшмәкәрләре милкендә була. Аларның иң эреләре — «Ә.Сәйдәшев, аның уллары һәм Б.Субаевның сәүдә-сәнәгать ширкәте» («Торгово-промышленное товарищество А.Сайдашева с сыновьями и Б.Субаев»), «И.Арслановның сабын кайнату һәм глицерин заводлары ширкәте» («Товарищество мыловаренного и глицеринового заводов И.Арсланова»), «Алафузовлар завод-фабрикаларының сәүдә-сәнәгать ширкәте» («Общество Алафузовских фабрик и заводов»), «Бертуган Крестовниковлар ширкәте» («Товарищество братьев Крестовниковых»), «Д.И.Вараксин варислары» («Наследники Д.И.Вараксина»), «Стахеев концерны» («Концерн Стахеева») һ.б.

Окт. рев-циясеннән соң С.гә дәүләт монополиясе урнаштырыла (1918), дәүләт һәм кооперация С.се оештырыла, хосусый сәүдәгәрләрне кысрыклап чыгару башлана. Товарларга кискен кытлык туу аркасында куллану предметларын үзәкләштерелгән бүлү кертелә (к. *«Хәрби коммунизм»*). *Яңа икътисади сәясәт* чорында көйләүле базар мөнәсәбәтләре гамәлдә була, ваклап сатуда товар әйләнеше арта һәм, *җәмәгать тукленуын* кертеп, 80,8 млн. сум тәшкил итә. Товар әйләнешенең 74% тан артык өлеше хосусый С. хисабына формалаша, 18,6% ы — дәүләт, 7% ы кооперация секторларына туры килә (1924). 1929–34 тә азык-төлек һәм сәнәгый товарларны бүлүнең нормаланган карточка системасы гамәлдә була, бәяләр сатуда товар әйләнеше 2,4 тапкыр (195,2 млн. сумга кадәр) үсә. Дәүләт алдындагы йөкләмәләрне үтәү шарты б-н колхозларга а.х. продукциясен базарларда сату рөхсәт ителә, әмма халыкка сәнәгый товарларның сату күләмендә колхоз С.сенең чагыштырмача өлеше 5% тан артмый. Шәһәрләрдә һәм авыл җирендә С. алга таба үсеш кичерә, халыкны иң кирәкле товарлар б-н тәэмин итү сизелерлек яхшыра.

Бөек Ватан сугышы елларында халык сәнәгый һ.б. иң кирәкле товарлар б-н бүлүнең нормаланган карточка системасы нигезендә тәэмин ителә (1947 дә бетерелә). 1950 дә ваклап сату С.сенең күләме сугышка кадәрге үсеш дәрәҗәсеннән арта, җәмәгать тукленуын (43,3 млн. сум) кертеп, 379 млн. сум (1940 ка караганда 2,4 тапкыр артыграк) тәшкил итә. Авыл җирендәге С.нең өлеше гомуми товар әйләнешендә 36% була.

1960 елларда респ-када С. үсеше уңай үзгәреш кичерә. Матди-техник база ныгытыла: 8 сәүдә үзәге һәм 5 комплекс сафка баса. Казанда 260 С. урынлы түбәле базар төзелә һәм файдалануга тапшырыла. Авыл җирендә 2 мең С. урынлы 828 кибет, 45 җәмәгать тукленуы пр-тиесе ачыла. Ваклап сату С.се пр-тиеләренең гомуми саны 7,3 меңгә җитә. Товарларның ассортименты күпкә киңәя, мәдәният-көнкүреш һәм хуҗалык ихтыяҗлары өчен җитештерелгән товарларны сату арта. 1970 тә 42,6 мең кеше эшләүче 8207 С. пр-тиесе исәпләнә, ваклап сату С.се әйләнеше 1708 млн. сум тәшкил итә (чагыштырма бәяләрдә), шуның 560,3 млн. сумы кооперация С.сенә, 170,4 млн. сумы җәмәгать тукленуы пр-тиеләренә туры килә.

1970 елларда С. пр-тиеләрен төзү һәм реконструкцияләү дәвам итә. 1977 дә Казанда, 15–16 йөзләрдә Ташаяк ярминкәсе эшләгән урында, 33 мең $м^2$ мәйданлы Үзәк универмаг (хәзер «Казан үзәк универмагы» сәүдә йорты АҖ) файдалануга тапшырыла. «Океан», «Яшьлек», «Радиотехника», «Балалар дөньясы» фирма кибетләре, Әлмәт, Яшел Үзән, Чаллыда һ.б. шәһәрләрдә универмаглар һәм универсамнар ачыла.

Совет чорында катгый рәвештә күмәртәләп эш итүче пр-тиеләр — җитештерү пр-тиеләренә, ваклап сатучы пр-тиеләр күмәртәләп эш итүче пр-тиеләргә беркетелә; продукция (товарлар) дәүләт тарафыннан үзәкләштерелгән рәвештә планлы нигездә бүленә. Җитештерү чараларыннан бүлүне Татглавснаб, Татсельхозснаб һ.б. башкара; куллану товарлары б-н күмәртәле С. Сәүдә министрлыгы системасында туплана һәм товарлар төркемнәре яки төрләре буенча махсуслашкан оешмалар — Мясорыбторг, Бакалейторг, Текстильторг, Торгодежда, Обувьторг, Хозторг, Культторг һ.б. тарафыннан гамәлгә ашырыла. Татарстан кулланучылар берлеге (Татпотребсоюз) үзе дә күмәртәле С. б-н шөгыльләнә (хәзерге вакытта да саклана, ш.у. а.х. продукциясен сатып ала һәм сата). 1987 дә ТАССРның күп кенә пр-тиеләре һәм оешмалары күмәртәле С. нигезендә матди-техник ресурслар б-н тәэмин итүгә күчерелә; СССР Госснабының Татарстан коммерция үзәге эшли башлый. 1980 дә ваклап сату С.се пр-тиеләренең саны 8435 кә җитә, шуларның 5036 сы — кооперация, 3389 ы — җәмәгать тукленуы пр-тиеләре; эшләүчеләр саны — 58,6 мең кеше; товар әйләнеше 3,2 млрд. сум (чагыштырма бәяләрдә 1940 елдагыга караганда 23 тапкыр күбрәк), ш.и. кооперациядә — 927,6 млн. сум, җәмәгать тукланышында 318,7 млн. сум тәшкил итә; гомуми әйләнеш структурасында азык-төлек товарларына 54,4% туры килә. 1983 тә товар әйләнеше 3,4 млрд. сум тәшкил итә (1976 дагыга караганда 35% ка күбрәк). Шулай да 1990 еллардагы реформаларга кадәр респ-ка халкы куллану товарларына кискен кытлык кичерә. 1979–93 тә азык-төлек товарлары һ.б. кайбер товарлар (мәс., юу чаралары) талоннар буенча билгеләнгән нормаларда сатыла. Озак файдаланулы товарлар (автомобильләр, суыткычлар, кер юу машиналары, телевизорлар, йорт җиһазлары, келәмнәр һ.б.) пр-тиеләрдә һәм оешмаларда чират тәртибендә бүленә.

1990 еллар башында ирекле С. рөхсәт ителгәч һәм бәяләрне ирекккә җибәргәннән соң, стационар С. б-н бергә стихияле рәвештә урам С.се барлыкка килә, тиз арада бәяләр күтәрелә. 1993–95 тә, бөтенроссия «шок терапиясе»ннән аермалы буларак, ТРда респ-каның базарга йомшак керү моделе гамәлгә ашырыла, шул рәвешчә төп туклану товарларына бәяләрнең кискен артуын тоткарлау мөмкин була. Әмма 1990 еллар ахырына халыкның сатып алу сәләте күпкә түбәнәя, 1999 га ваклап сату товар әйләнеше (1990 га карата чагыштырма бәяләрдә) 23,3% ка кими.

С. пр-тиеләрен хосусыйлаштыру нәтиҗәсендә С. эшмәкәрлеге барлыкка килә, бу тәэминатның җанлануына, товарлар кытлыгын, чиратларны һәм бүлүнең талон системасын бетерүгә булышлык итә. Җиһазлар, транспорт чаралары, а.х. һәм авиация техникасы сатуда лизинг куллануга керешәләр. 2000 нән башлап ваклап сатуда товар әйләнеше үсә башлый, 2002 дә 1990 ел дәрәҗәсенә ирешә, 2005 тә аны 1,7 тапкыр узып китә, алдагы елларда зур темплар б-н үсә.

1990 елларның 2 нче яртысыннан Татарстанның куллану базарында респ-каның «Эдельвейс» сәүдә компаниясе», «ДОМО» компанияләр төркеме», «Бәхетле-1», «Чаллы икмәге» сәүдә йорты», «Ак Барс Торг» («Пятёрочка» кибетләре челтәре»), «Оптовик» («Эссен» челтәре), «Камилла» сәүдә йорты», «Агава» («Мегастрой»), федераль челтәрләр һәм компанияләр — «Перекрёсток» («Перекрёсток», «Карусель» челтәрләре), «Тандер» («Магнит» челтәре), «Балалар дөньясы» АҖләре; «Вестерритейл» («Вестер-Гипер», «Сосед» челтәрләре), «Омега-97» фирмасы» («Патэрсон» челтәре), «М.видео Менеджмент», «DIXIS», «Эльдорадо», «Максидом», чит илләрнең «ИКЕА Мос» (Швеция), «Метро Кэш энд Керри», «ОБИ», «Зельгросс Кэш энд Керри» һәм «реал-Гипермаркет» (Германия), «Ашан-Группа Рус», «Леруа Мерлен» (Франция) кебек эре С. челтәрләренең һәм компанияләренең роле үсә. Алар катнашында заманча С. җиһазлары урнаштырылган, килүчеләр, сатып алучылар өчен кинотеатрлар, рестораннар, кафелар, уен заллары, балалар бүлмәләре һ.б. булган гипер- һәм супермаркетлар төзелә. Өр-яңа технологияләр һәм сатып алучыларга хезмәт күрсәтүнең инновацион формалары, интернет аша электрон С. системасы гамәлгә кертелә. Инфраструктура (суыткычлар, складлар, саклау урыннары, транспорт, автомобиль кую урыннары) үсеш кичерә. «Эдельвейс» сәүдә компаниясе», «Перекрёсток» сәүдә йорты», «Бәхетле», «реал-Гипермаркет», «Омега-97» фирмасы» компанияләре азык-төлек товарларын үзләре житештерәләр. Якын арадагы — клиентлар яшәгән урыннар тирәсендәге С. пр-тиеләре челтәре барлыкка килә; «хәләл» кибетләр ачыла. 2014 тә ваклап сату С.се әйләнеше структурасында төрле рәвештәге (махсуслаштырылган дискаунтерлардан гипермаркетларга кадәр) С. челтәрләренең өлеше 21,5% (2013 тә — 19,7%) тәшкил итә.

Гаять зур күмәртәле-ваклап сату С.се комплекслары — «Яңа Тура» технополисы (2012, Яшел Үзән р-ны), «Казан» агросәнәгать паркы (2013) төзелеп, файдалануга тапшырыла.

2014 тә респ-када 16 меңнән артык ваклап сату С.се пр-тиесе эшли, аларның 99%ы дәүләти булмаган милеккә карый. 29 мең С. урынлы 100 дән артык базар (азык-төлек, әйберләр, катнаш базарлар) исәпләнә. Куллану базары өлкәсендә 300 меңнән артык кеше (икътисади актив халыкның 17%ы) эшли. Ваклап сатуда товар әйләнешенең күләме 781 млрд. сумнан арта (2013 тә — 713 млрд. сум). Бу товар әйләнеше структурасында азык-төлек товарларының чагыштырма өлеше — 43,5% (2013 тә — 42,7%), азык-төлек булмаган товарларныкы 56,5% (57,3%) тәшкил итә. 2013 тә күмәртәле С. оешмаларының товар әйләнеше — 641,9 млрд. сум.

Ваклап сату С.се әйләнешенең 91,9%ы стационар С. челтәрендә формалаша (эре оешмалар һәм урта күләм эшмәкәрлек субъектлары — 42,8%, шәхси эшмәкәрләр — 31,4%, кече һәм вак пр-тиеләр — 17,7%). Ваклап сату С.се әйләнешендә базарлар һәм ярминкәләр өлешенә 8,1% туры килә. С. объектларының мәйдан б-н минималь дәрәҗәдә тәэмин ителеше норматившыннан артып, мең кешегә исәпләгәндә, С. мәйданнары респ-ка буенча уртача 752 $м^2$ тәшкил итә. Ваклап сату С.се әйләнешенең 90% тан артык өлеше шәһәрләргә, ш.и. 60% чамасы Казанга, 20% тирәсе Чаллыга туры килә. Шуңа бәйле рәвештә эре шәһәрләрдә генә түгел, халыкның зур өлеше яшәгән авыл җирендә дә куллану базарының заманча объектларын үстерү өстенлекле мәсьәләләрнең берсе булып кала. Шулай ук респ-ка пр-тиеләре продукциясе хәрәкәтен активлаштыру, сатып алучыларның җирле продукциягә даими ихтыяҗын формалаштыру буенча чаралар комплексы гамәлгә ашырыла.

Татарстан РФнең барлык субъектлары б-н С. хезмәттәшлеге җәелдерә. ТР б-н аеруча актив С.-икътисади хезмәттәшлек итүче төбәкләр исәбенә Мәскәү, Ленинград, Курган, Самара, Чиләбе, Калуга, Түбән Новгород һәм Свердловск өлкәләре, Башкортстан Респ-касы керә (аларга ТРның гомуми төбәкара С. әйләнешенең 66% тан артык өлеше туры килә). РФ субъектларына нефть, машиналар төзү, химия һәм нефть химиясе продукциясе, халык куллану товарлары һ.б. җибәрелә. Респ-кага кара металл прокаты, корыч торбалар, автокраннар, төзелеш материаллары, дизель ягулыгы, халык куллану товарлары һ.б. кертелә. 2013 тә төбәкара товар әйләнеше 509,5 млрд. сум (ш.и. чыгару — 310,4 млрд. сум, кертү — 199,1 млрд. сум) тәшкил итә.

1990 еллар башыннан Татарстан актив рәвештә якын һәм ерак чит илләр б-н С.-икътисади мөнәсәбәтләр җәелдерә. 1992–2013 тә респ-каның тышкы С. әйләнеше 26 тапкыр арта. Экспорт — 22,4 млрд., читтән кертү 5,2 млрд. долларга җитә. Экспортның 90%ы һәм читтән кертүнең 80%ы ерак чит илләргә туры килә. 2013 тә 130 ил Татарстанның С. партнёры була, алар арасында мөһим урынны Нидерланд (тышкы С. әйләнешенең 23%ы), Польша (9,6%), Италия (8,5%) һәм Венгрия (6%) били. Респ-ка продукциясен 120 ил сатып ала, товарлар 105 илдән кертелә. Читкә чыгару структурасында нефть һәм нефть продуктлары (78,3%), ясалма каучук һ.б. химия продуктлары (10,7%), транспорт чаралары, җиһазлар, приборлар (8,5%) өстенлек итә. Читтән кертелүче товарларның чагыштырма өлешендә күпчелек машиналарга, приборларга, җиһазларга, транспорт чараларына һәм аларның өлешләренә, механизмнарына туры килә (81%).

*Әд.:* Материалы для географии и статистики России, собранные офицерами Генерального штаба. Т. 8. Казанская губерния / Сост. М.Лаптев. СПб., 1861; Базары Казанской губернии // Тр. Казан. губерн. стат. комитета. 1869. Вып. 1; История Казани: В 2 кн. К., 1988–91; Свердлова Л.М. На перекрёстке торговых путей. К., 1991; шул ук. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998; Валеев Р.М. Волжская Булгария: торговля и денежно-весовые системы IX — начала XIII веков. К., 1995: Золотые страницы купечества, промышленников и предпринимателей Татарстана: В 2 т. К., 2001; История татар с древнейших времён. Т. 2. Волжская Булгария и Великая степь. К., 2006; Когин А.А. Торговля: успех в делах очевиден // Элита Татарстана. 2008. Июль–авг.

*М.Ж.Гаитов, Е.П.Иванов.*

**СӘҮДӘГӘРЛӘ́Р**, сәүдә-эшмәкәрлек б-н шөгыльләнүче социаль катлау. Россиядә 1775 елгы закон нигезендә шәһәр сәүдә-сәнәгать катлавы буларак формалаша.

Төбәк терр-ясендә сәүдә традицияләре борынгы заманнардан ук барлыкка килә, ләкин С. үсеше тарихында *Идел буе Болгар дәүләте* һәм *Алтын Урда* чорлары иң әһәмиятле дәверләрнең берсе була. Археол. һәм язма чыганаклардан күренгәнчә, Болгар һәм Биләр шәһәрләренә Ираннан, Кытайдан, Һиндстаннан, Византиядән, Русьтан һ.б. дәүләтләрдән товарлар китерелә, *Ибне Фадлан* да Болгарда сәүдәгәрләр күп булуын билгеләп уза. 10 йөз ахырында — 11 йөз башында ук С. дәүләттә аерым социаль төркем тәшкил итә. Сәүдә Алтын Урдада, соңрак *Казан ханлыгында* үсеш кичерә. Казанның геогр. һәм икътисади яктан җайлы урында — зур кәрван һәм су юллары буенда урнашуы 15–16 йөзләрдә С. катлавының тиз үсүенә һәм халыкара зур ярминкәләр барлыкка килүгә китерә (к. *«Маркиз» утравы*, Җәйге Арча ярминкәсе, *Ташаяк* һ.б.). Шәһәрдә чит ил сәүдәгәрләре бистәләре барлыкка килә (к. *Әрмән бистәсе*).

Казан ханлыгын Рус дәүләте яулап алганнан соң (1552), төбәктә С. катлавы Россиянең һәр төбәгендәге шикелле үк формалаша. С. шәһәр катлауларының өстенлекле төркеменә карыйлар. Рәсми документларда С.нең аеруча бай вәкилләрен «кунаклар» дип атыйлар, алар «йөк»тән (йөкләмәләрдән) азат ителәләр, җир биләмәләренә хуҗа була, юл пошлиналарын түләмичә генә чит илгә бара алалар. 1560 елларда Казанда 23 кеше «кунаклар» булып исәпләнә (аларның 20 се башка шәһәрләрдән килә). Шәһәр катлауларының башка вәкилләре: *бистә халкы*, стрелецлар, казаклар, тупчылар да сәүдә алып баралар. Шулай да проф. сәүдәгәрләр аз була, күбрәк җитештерүчеләр үзләре сату-алу б-н шөгыльләнә. 16 йөз ахырында Казан сәүдә пошлиналары җыю буенча (бер елга 11 мең сум тәшкил итә) Мәскәү дәрәҗәсенә (бер елга 12 мең сум) якынлаша. Казанда *Гостиный двор* шәһәр сәүдәсе үзәгенә әверелә. Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, төбәктә рус булмаган сәүдәгәрләр саны аз була: чыганакларда Казанда сәүдә иткән 425 кешенең 5 се генә «басурманнар» (мөселманнар) дип күрсәтелә. Рус дәүләте сәясәте нәтиҗәсендә татарларга сәүдә алып бару тыелу, аларны шәһәрләрдән көчләп куып чыгару һәм төрле чикләүләр (к. *Тыелган товарлар*) татарларның шәһәрләрдә сәүдә эшчәнлеге кимүгә китерә. 17 йөздә С. формалашу дәвам итә.

17 йөздә шәһәрдә «кунаклар» саны кими (1640 елларда нибары 1 утар). Мәскәүдә теркәлгән һәм ш.у. зур өстенлекләре булган кунак һәм постау йөзлекләре вәкилләре бер баскыч түбәнрәк торалар. Бу катлау вәкилләрен Мәскәүдән башлыклар һәм целовальниклар дәрәҗәсендә башка шәһәрләргә казна эшләре б-н идарә итәргә җибәрәләр. 17 йөздә алыпсатарлар эшчәнлеге җәелә: 1646 да Казанда аларның саны 200 гә якынлаша. 1649

елгы Кануннар мәҗмугасы бистәнең кара халкына сәүдә һәм кәсепчелек итүгә хокук бирә, ш.у. тиешле салымнарны һ.б. бурычларны билгели. Шәһәрләрнең сәүдә роле күбесенчә дәүләт күрсәтмәләренә бәйле. Мәс., патша фәрманнары буенча, Шәрекъ С.ләре Әстерханда һәм Казанда гына сәүдә итә алалар, бу транзит сәүдәдә әлеге шәһәрләрнең әһәмиятен күтәрә. Сәүдә рәтләреннән читтә сәүдә итү тыела; һәр рәттә билгеле бер төрдәге товарлар гына сатыла. Патша Алексей Михайлович заманында һәр якшәмбе һәм зур христиан бәйрәмнәре көннәрендә, иконалар күтәреп йөргәндә, һәр шимбә көнендә (чиркәүләрдә кичке гыйбадәт башланганчы) сәүдә итү вакытын чикләгән фәрман чыга. Мөселман С., үзләренең дини бәйрәмнәре һәм ял көннәре булуга карамастан, гомуми нигезләмәгә буйсынырга мәҗбүр булалар, аны бозган өчен штраф карала. Мөселман С. берничә тапкыр хөкүмәт алдында Россия законнарының христиан дине үзенчәлекләрен генә түгел, ислам дине үзенчәлекләрен дә искә алырга тиешлеге турындагы мәсьәләне куялар. 17 йөздә С. капиталының а.х. һәм сәнәгать җитештерүе б-н бәйләнеше көчәя, бу төбәктә яңа иҗтимагый сыйныф — *буржуазия* барлыкка килүгә китерә. 1685 тә татарларга сәүдә эшчәнлеге б-н шөгыльләнүгә чикләүләр бетерелә, шул рәвешле бу вакытка урнашкан халәт законлаштырыла. Миграция нәтиҗәсендә кайбер татарлар Россия империясенең башка төбәкләрендә төпләнеп калалар. Чыганаклардан күренгәнчә, татарлар илнең төрле почмакларында сәүдә итәләр. Мәс., 1650 дә Бөек Устюгта 13 карин (Чепья) татары теркәлгән. Татарлар Россиянең Казакъстан һәм Урта Азия илләре б-н сәүдә-икътисад бәйләнешләрен җайга салуда зур роль уйныйлар. Россиянең барлык зур ярминкәләрендә дә татар С.енең үз сәүдә рәтләре була (к. *Эрбет ярминкәсе, Мәкәрҗә ярминкәсе*). Төбәктә С.нең формалашуы күп очракта икътисад үсеше б-н дә билгеләнә. 17 йөздә Казан төбәге С.не транзит сәүдә үзәге буларак кына түгел, төрле һөнәрчелек (тире-күн, сабын кайнату, зәркәнчелек, тимерчелек һ.б.) үзәге буларак та җәлеп итә. 17 йөздә анда беренче *мануфактуралар* барлыкка килә, аларга бай С. нигез сала һәм хуҗа була.

Император Пётр I Фәрманы нигезендә бистә халкы арасында С.нең 2 гильдиясен аера башлыйлар. Император Елизавета Петровна вакытында (1742) рәсми рәвештә 3 гильдия билгеләнә (ценз үзгәрә). Гильдияләрне сайланган старосталар җитәкли, алар С.дән салымнар җыялар. Ул вакытта С.гә рекрут йөкләмәсен үтәмәү, моның өчен акчалата түләү (сумма һәрвакыт үзгәрә) рөхсәт ителә. С. йөкләмәләрне үзидарә органнарында да — *магистратларда* бурмистрлар, ратушаларда судья һ.б. булып үтәргә тиеш булалар. Гильдия С.енең хокуклары һәм бурычлары 1775 нең 17 март Манифестында һәм 1785 тәге шәһәрләргә өстенлекләр грамотасында тулысынча формалаша; киләчәктә законнар С.нең хокукый статусын тәгаенли һәм тулыландыра. Гильдия С.е булып 500 сумнан күбрәк капиталлары булуын игълан иткән бистә халкы языла: алар җан башыннан түләнә торган салымнан азат ителәләр, ләкин казнага гильдия салымын — игълан ителгән капитал суммасыннан процент (1775 тән 1821 гә кадәр салым күләме 1% тан 5,2% кадәр арта) түләргә мәҗбүр булалар. Капитал суммасын белдерү намус эше буларак карала. 3 гильдия кертелә: 1 нчесе — капиталы 10 мең сумнан арткан С. өчен; 2 нчесе — 1 меңнән 10 мең сумга кадәр; 3 нчесе — 500 сумнан 1000 сумга кадәр капиталы булган С. өчен. 1 нче гильдиядә булу илдә һәм чит илдә, күпләп һәм ваклап сату, фабрика һәм заводлар ачу, диңгез суднолары тоту хокукы; 2 нче гильдиядә исәпләнү — илдә сәүдә итү, фабрика һәм заводлар ачу, елга судноларына хуҗа булу; 3 нче гильдиядә тору сәүдәгәр үзе теркәлгән шәһәрдә һәм өяздә вак сәүдә эшләре алып бару, остаханәләр булдыру, кечкенә елга судноларына хуҗа булу, трактирлар, мунчалар һәм кунып чыгу йортлары тоту хокукы бирә. 1789–91 дә Казанда С. гильдияләренә 237 кеше: аларның 10 сы — 1 нче гильдиягә (В.В.Евреинов, А.С.*Иноземцев*, Г.П.*Каменев*, *Кобелевлар*, П.П.Петров, А.Б.Ростовцов, П.Д.Смирнов, П.П.Шварев), 31 е — 2 нчегә (ш.и. 10 татар: М.Габдрәшитов, У.Баязитов, Г.Исхаков, А.Мәсәгутов, Г.Мөслимов, В.Мөслимов, С.Нәзиров, Х.Сәгыйтов, У.Уразмәтов, М.Үтәмишев), 196 кеше 3 нче гильдиягә языла. 1863 тә 3 нче гильдия бетерелә. 1801 дә С. халык яшәми торган җирләргә хуҗа булу, 1807 дә — сәүдә йортлары булдыру, 1836 да акц. компанияләрендә катнашу хокукына ирешә. 1 нче гильдия С.енә сәүдәгәр үзе теркәлгән терр-янең губерна мундиры, ш.у. шпага яки кылыч йөртү хокукы бирелә. 1807 дән атаклы С. нәселләренең «Бәрхет китаплары» төзелә башлый. 1 нче гильдия С.е атаклы граждан (1785–1807), беренче дәрәҗәле сәүдәгәр (1807–24), негоциант яки банкир (1824 тән), нәселдән килгән яки шәхси граждан (1832 дән) дәрәҗәләренә ия була алалар. Россия орденнарының берсе бирелгәндә, ш.у. 10 ел дәвамында өзлексез 1 нче гильдиядә торганда сәүдәгәр нәселдән килгән мактаулы гражданлыкны ала. Алга таба нәселдән килгән мактаулы гражданлык хокукына 2 нче гильдия сәүдәгәрләре — орден бирелгәндә яки 20 ел өзлексез гильдиядә булган очракта ирешә. Казанда беренче нәселдән килгән мактаулы гражданнар — сәүдәгәр П.И.Котелов һәм Л.Ф.Крупеников гаиләләре (1833), бераз соңрак *Апаковлар, Апанаевлар, Арсаевлар*, Вараксиннар, Заусайловлар, *Казаковлар, Усмановлар, Юнысовлар* һ.б.ның гаиләләре. 1800 дән сату-алу эшчәнлегендәге уңышлар өчен С.гә коммерция киңәшчесе, 1807 дән мануфактура киңәшчесе (гражданнар хезмәтенең 8 нче чинына хокук бирә) дәрәҗәләре бирә башлыйлар. Шушы ук дәрәҗәләр шәхси дворяннлык хокукын тәэмин итә. Казанда беренче коммерция киңәшчесе дәрәҗәсен беренчеләрдән булып сәүдәгәр А.И.*Квасников*, соңрак сәүдәгәрләр Г.П.Каменев, бертуганнар Ибраһим һәм Исхак Юнысовлар, С.Е.Александров ала; мануфактура киңәшчесе дәрәҗәсенә И.И.*Алафузов*, бертуган *Крестовниковлар* һ.б. лаек була. 1824 елгы сәүдәгәрләр гильдиясе турындагы карар нигезендә С. түбәндәгеләрне үз өсләренә алалар: 1 нче гильдия сәүдәгәрләре — шәһәр башлыклары, җинаять һәм гражданнар палаталарында утырышчылар, вөҗдан мәхкәмәләрендә, җәмәгать тәрбиясе приказларында судьялар, банк һәм аларның конторалары директорлары, чиркәү старосталары вазифалары; 2 нче гильдия сәүдәгәрләре — шәһәр магистратларында, бургомистрлар, ратманнар, мәхкәмә әгъзалары вазифалары; 3 нче гильдия сәүдәгәрләре — шәһәр старосталары, алты гласныйлы шәһәр думасы әгъзалары, фатир комиссиясендә депутат вазифалары һ.б. 18 йөз ахырында — 19 йөзнең 1 нче яртысында шәһәр идарәсе тулысынча диярлек С. кулында була. Шуның б-н бергә татар С.е вәкилләре гражданнар һәм җинаять палаталары утырышчылары, вөҗдан мәхкәмәсе әгъзасы вазифаларына гына рөхсәт алалар. 1824 тән Казан шәһәр думасы каршында сәүдә һәм һөнәрчелек эшчәнлегенә карата билгеләнгән кагыйдәләрнең үтәлешенә күзәтчелек иткән сәүдә депутациясе эшли. Сәүдә депутациясе әгъзаларын С. арасыннан — 3, ә 1870 тән 4 елга сайлыйлар. Казанда сәүдә депутациясенә 5 әгъза һәм 5 кандидат сайлана, аның составына татарлардан бер вәкил кертелергә тиеш була. Депутация ел саен барлык сәүдә оешмаларын, үлчәү берәмлекләрен һәм үлчәүләрне тикшерә, товарларның сыйфатлылыгын күзәтчелек итә. 1846 га кадәр С. эшләре шәһәр думалары карамагында була. Соңрак С.гә үзидарә хокукы бирелә, күп кенә шәһәрләрдә сәүдә идарәләре барлыкка килә, алар һәр ел саен староста җитәкчелегендә сәүдәгәрләр җәмгыяте тарафыннан сайлап куела, губернатор старостаның вазифага керешүен раслый. Сәүдәгәрләр оешмасы ш.у. Казан губерна йөкләмәләр кабулханәсе утырышларында катнашу өчен әгъза һәм кандидат, сәүдә рәтләре старосталары һ.б.ны сайлый, төрле гаризаларны тикшерә һ.б. 1860–70 еллардагы реформалардан соң С.нең катлау хокукларының һәм өстенлекләренең роле кими, 19–20 йөзләр чигендә алар декоратив характерда булалар: сәүдәгәрләр гильдияләргә кирәк булганга түгел, дәрәҗә өчен язылалар, чөнки башка катлаулар вәкилләре өчен сәүдә б-н шөгыльләнүгә тыюлар бетерелә.

18 йөздә Казан губернасында сәнәгать һәм а.х. актив үсеш кичерә. С. эшчәнлеге нәтиҗәсендә төбәктә беренче сәнәгать пр-тиеләре барлыкка килә: мәс., сәүдәгәр И.А.*Михляев* Казанда төбәктәге иң зур постау мануфактурасы, 1718 дә Апанаев һәм Әбсәләмов күн з-длары, Ходайгулов Арчадан ерак түгел комач мануфактурасы (к. *Комач мануфактуралары*) ача. 18–19 йөзләрдә Казан — Россиянең эре сәүдә үзәге. 1773 тә Гостиный дворда 776 кибет исәпләнә, аларның бер өлеше татар С. милкендә була. Зур су юлларында — Камада һәм Вяткада урнашкан Алабуга, Лаеш, Мамадыш, Минзәлә, Чистай шәһәрләре а.х. продуктларының мөһим базарларына әверелә. Зур базарлар Тәтеш, Зөя шәһәрләрендә, Алат, Әтнә, Мәңгәр, Байлар Сабасы һ.б. авылларда эшли. 1781–82 дә Казан губернасы буенча С.: Лаешта — 1 йорт (гаи-

лә), Царёвококшайскида — 9, Чабаксарда — 19, Козмодемьянскида — 19, Ядриндә — 33, Цивильскида — 24, Зөядә 54 йорт. 1860 та губернада 5448 сәүдәгәр (гаилә әгъзаларын да исәпләп) яши.

19 йөздә — 20 йөз башында С. төбәк тарихында мөһим роль уйныйлар: актив рәвештә иганәчелек б-н шөгыльләнәләр, алар акчасына балалар ятимханәләре (к. *Александра исемендәге балалар ятимханәсе, Николай исемендәге балалар ятимханәсе, Юнысовлар балалар ятимханәсе*), гарипләр йортлары, ашханәләр һ.б. ачыла; шәһәр думасы эшендә катнашалар. С. корпоратив мәнфәгатьләрне дә яклыйлар, шуның б-н бәйле рәвештә Казанда 1861 дә *Сәүдәгәрләр клубы*, 1866 да *Сәүдәгәрләр биржасы*, 1873 тә *Сәүдәгәрләр банкы*, 1898 дә *Казан сәүдәгәрләренең үзара ярдәмләшү җәмгыяте* һ.б. оештырыла. 19 йөздә Казан губернасында иң зур капиталларга Алафузовлар, *Александровлар*, Апаковлар, Апанаевлар, Журавлёвлар, Казаковлар, Крестовниковлар, Сәйдәшевләр, Шамовлар, Юнысовлар гаиләләре ия була. Төбәкнең иң бай С. нәселләренең берсе булып *Стахеевлар* гаиләсе исәпләнә. Чистай сәүдәгәрләре арасында шактый зур капитал В.Л.Челышев, Е.П. һәм П.П.Шашиннар, Г.А., Д.А. һәм И.Д.Поляковлар кулында була.

18–19 йөзләрдә татар С.е катлавы актив үсеш кичерә, бу Екатерина II нең сәүдә өлкәсендәге либеральлек сәясәте б-н бәйле. 18 йөзнең 2 нче яртысыннан татар С.енә дә рәсми рәвештә гильдияләргә язылу хокукы бирелә. 1781 дә татар С.е эшләрен алып бару өчен *Казан шәһәре татар бистәләре ратушасы* оештырыла. 1790 да 3 нче гильдиягә беренчеләрдән булып йомышлы татар Мортаза Колмәмәтов, соңыннан Йосып Китаев языла, 1795 тә 2 нче гильдиягә Габдерәшит Рахманкулов кабул ителә. 1799 да сәүдәгәрләр гильдияләрендә Казанның йомышлы татарларыннан 32 гаилә: 8 е — 2 нче гильдиядә, 24 е 3 нче гильдиядә исәпләнә. 18–19 йөзләрдә С. капиталының а.х.нда һәм сәнәгатьтә җитештерү б-н бәйләнеше сизелерлек көчәя, татар С.е комач, күн, сабын кайнату, бөз мануһ.б. пр-тиеләр хуҗаларына әверелләләр. Россиянең башка илләр, аеруча Урта Азия, Кытай һ.б. б-н сәүдә мөнәсәбәтләрен җанландыруда татар С.енең роле шактый үсә (к. *Каргалы бистәсе, Ташкент кәрваны*). 1751–52 дә Оренбург сәүдәгәре И.*Бикмөхәммәтов* татар С.е Н.Сәфәров, Я.Ягъфәров һ.б. б-н берлектә Һиндстанга сәяхәт кыла.

Татар С.е Казан губернасының иҗтимагый һәм икътисади тормышында зур роль уйныйлар, алар милли мәдәният үсешенә зур йогынты ясыйлар. Татар С.е арасында күренекле хәйриячеләр күп була, алар акчасына мәдрәсәләр һәм мәктәпләр ачыла һәм тотыла, мәчетләр төзелә, китаплар һәм газеталар нәшер ителә (к. *Иганәчелек*). 1898 дә алар башлангычында *Казан шәһәр мөселманнары хәйрия җәмгыяте* оештырыла. Реформа чорында татар С.е арасында милли буржуазия формалаша башлый. Товар җитештерү б-н бәйле сәүдә-арадашчылык капиталы алга таба үсеш кичерә. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан пайларга нигезләнгән, акц. җәмгыятьләре тибындагы сәүдә йортлары оештыру тенденциясе күзәтелә. 1877–1900 дә Казанда гына татарларның 15 сәүдә йорты теркәлә; 1872–1916 да 300 гә якын сәүдә йорты һәм акц. җәмгыяте исәпләнә, шуларның якынча 28% ы татарлар милкендә була. Иң зурлары: «Ә.Сәйдәшев, аның уллары һәм Б.Субаевның уртак сәүдә-сәнәгать ширкәте» (1895), «И.Арслановның сабын кайнату һәм глицерин заводлары ширкәте» (1900). 1914 тә Россиядә татар С.е 155 тән артык сәүдә йортына ия булалар (гомуми капиталлары 5,9 млн. сум). «Алафузовлар завод-фабрикаларының сәүдә-сәнәгать ширкәте», «Бертуган Крестовниковлар ширкәте», «Д.И.Вараксин варислары», «Стахеев концерны» төбәктәге иң зур сәүдә-сәнәгать ширкәтләре буларак танылалар.

1897 елгы Гомуми халык исәбен алу мәгълүматлары буенча, Россиядә 3737627 татар исәпләнә (саннар төгәл түгел, чөнки кайбер Кавказ халыкларының, Кырым татарларының һ.б.ның вәкилләрен еш кына татар дип язалар), шулардан 417727 кеше шәһәрләрдә яши. Гаилә әгъзалары исәпкә алынган С. — якынча 7066 кеше, гаиләсезләр — 1289 кеше. Татар С.енең губерналар буенча бүленеше түбәндәгечә: Әстерхан губернасы — гаиләсез 2 сәүдәгәр, Казан губернасында — 52, Самара губернасында — 8, Сембер губернасында — 19, Оренбург губернасында — 189, Уфа губернасында 147 кеше; Россиянең Европа өлешендә — 924, Кавказда — 106, Себердә — 59, Урта Азиядә — 52 кеше. Казан губернасыннан читтә татар С.е арасында зур капиталларга ия булучылар — *Акчуриннар* (Сембер губ.), *Дебердиевлар* (Саратов губ.), *Рәмиевләр* һәм *Хөсәеновлар* (Оренбург губ.). 1917 дән соң С. катлавы юкка чыга.

*Әд.:* Х а с а н о в Х.Х. Формирование татарской буржуазной нации. К., 1977; А л и ш е в С.Х. Исторические судьбы народов Среднего Поволжья XVI — начала XIX в. М., 1990; С в е р д л о в а Л.М. На перекрёстке торговых путей. К., 1991; ш у л у к. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998; С а л и х о в Р.Р. Татарская буржуазия Казани и национальные реформы второй половины XIX — начала XX в. К., 2001.

*Л.М.Айнетдинова.*

**СӘҮДӘГӘРЛӘ́Р БА́НКЫ**, 1873 елның июлендә Казанда ачыла. Максаты: кыска вакытлы кредитлар биреп тору юлы б-н төбәк сәнәгатен һәм сәүдәсен җанландыру һәм үстерү. Казан сәүдәгәрләре А.С.Александров, Д.И.Вараксин, М.И.Попов, Л.Н. һәм Н.Н.Урванцовлар, Минзәләдән вакытлы сәүдәгәр М.А.Мешкичев, Мәскәүдән бертуган Елисеевлар һәм С.-Петербургтан Н.М.Полетаев башлангычында оештырыла. Татар сәүдәгәрләреннән С.М.Аитов, С.Галикәев, М.И.Үтәмишев һ.б. идарә әгъзасы булып торалар. А.С.Александров, М.И.Попов, Я.Д.Соколов, Я.Ф.Шамов идарә рәислегенә сайланалар. Банк акчалата керемнәр кабул итә; счётлар ача; вексельләр, кыйммәтле кәгазьләр, товарлар исәбен ала һәм алар б-н сату итә; вексельләр, кыйммәтле кәгазьләр, товарлар һәм товар документлары исәбенә ссуда биреп тора. Мәкәрҗә ярминкәсендә вакытлы бүлекчә тота. С.б.ның төп капиталы — 1 млн., запас капиталы (даими) 335 мең сум тәшкил итә; гомуми капитал әйләнеше: 198228910 сум (1907), 245974756 сум (1914); сроклы кертемнәр: 1823754 сум (1907), 2460808 сум (1914); махсус счётлардагы әйләнеш 9179106 сум (1907), 14642736 (1914). 1913 тә Казан С.б. Россия сәүдәгәрләр банклары арасында капиталы һәм балансы буенча 6 нчы урынны




Сәүдәгәрләр банкы бинасы. 1908.
Фотограф Частихин.


(Мәскәү, Лодзь, Одесса, Самара һәм Ростов-Доннан соң) били. 1907–14 тә аның капитал әйләнеше *Казан шәһәр җәмәгать банкының* капитал әйләнешеннән 5 тапкырдан артыграк була. 1917 нең декабрендә национализацияләнә.

*Әд.:* С в е р д л о в а Л.М. На перекрёстке торговых путей. К., 1991.

**СӘҮДӘГӘРЛӘ́Р БИ́РЖАСЫ**, даими эшләүче күмәртәләп сату базары. Н.К.Крестовников, И.Н.Соболев, С.Е.Александров башлангычында гамәлгә куела. Максаты: җитештерүчеләр, тәэминатчылар һәм сәүдә итүчеләр арасында ел әйләнә элемтә булдыру. Уставы 1866 елның 11 ноябрендә раслана, ачылышы — 1868 нең ноябрендә. С.б. эшчәнлеге б-н даими эшләүче сайланулы орган (Россия буржуазиясенең вәкаләтле оешмасы) — биржа ком-ты идарә итә. Биржа ком-ты биржадагы эш алып бару тәртипләрен көйләү; губернадагы һәм шәһәрдәге сәүдә, һөнәрчелек һәм сәнәгатьнең торышын өйрәнү; төрле проектлар (мәс., Казанда елга порты төзү, коммерция белеме бирүне үстерү) эшләү; мәгълүмат туплау һәм төрле белешмәләр тутыру (ш.и. хөкүмәт таләбе буенча да) кебек мәсьәләләрне үз карамагында тота. Биржа соста-



Сәүдәгәрләр биржасы бинасы.
20 йөз башы фоторәсеме.

Сәүдәгәрләр җыены бинасы. 1. 1903 елгы реконструкция. 20 йөз башы фоторәсеме. 2. 2004 елгы реконструкция. Хәзерге күренеше.

вына төбәкнең сәүдә капиталы вәкилләре К.И.Романов, И.Н.Соболев, И.Н.Журавлёв, М.Л.Свешников, А.А.Лебедев керә, ком-т старшиналары итеп Н.К. һәм И.К.Крестовниковлар, И.О.Тихомирнов, Я.Ф.Шамов һ.б. сайлана. Биржа ком-ты рәисе коммерция киңәшчесе дәрәҗәсе ала; беренче рәис — И.Н.Соболев, аның акчасына 1874 тә Зур Проломная (хәзер Бауман) урамында биржа бинасы төзелә. С.б.нда товар (башлыча, икмәк продуктлары) аукционнары уздырыла, сәүдә килешүләре төзелә (алар, гадәттә, атнага 2 тапкыр, көндезге сәгать 1 б-н 2 арасында була). Биржа килешүләре төзегәндә товар үзе түгел, ә аңа ия булу хокукы сатыла яки сатып алына. Биржа сәүдәсенең максаты — бәяләр аермасы аша табыш алу. Килешүләр төзегәндә арадашчы ролен маклерлар үти. Татар эшмәкәрләре б-н эш йөртү өчен, гадәттә, маклер итеп татар кешесе сайлана (1870 тән Г.Әхтәмов). Ул татар һәм рус сәүдәгәрләре, сәнәгатьчеләре арасында элемтә булдырырга тиеш була. Баштагы Устав буенча маклерларны гомерлеккә (1897 ел Уставы буенча — 3 елга, фәкать 12 сәүдә-сәнәгать фирмасы тәкъдиме б-н генә) генә билгелиләр, гильдияле сәүдәгәрләр вәкилләренә өстенлек бирелә. Маклерларга үзләре өчен операцияләр башкару тыела, килешү төзелгәннән соң, алар комиссия хакы алалар. Беренче гофмаклер — Н.П.Квасников (1867–87). Биржада килешүләр фәкать рус телендә теркәлә, шунлыктан татарлар аның эшендә сирәк катнаша. 1869 ел ахырында биржа каршында «Рус сәнәгате һәм сәүдәсенә ярдәм җәмгыяте» оеша (җитәкчесе С.Е.Александров, аннан соң — Н.К.Крестовников). Еллык әйләнеш 8 млн. сумга җитә (1882). С.б. *«Казанский биржевой листок»* г-тасын нәшер итә.

*Әд.:* С в е р д л о в а Л.М. На перекрёстке торговых путей. К., 1991; М у с т а ф и н а Г.М., М у н ь к о в Н.П., С в е р д л о в а Л.М. История Татарстана. XIX век. К., 2003.

*Л.М.Айнетдинова.*

**СӘҮДӘГӘРЛӘ́Р ҖЫЕНЫ́ БИНАСЫ́**, Казанда тарих һәм архит-ра истәлеге. Башта 1824 елда сәүдәгәр К.Е.Подуруев акчасына ярдәмче каралтылары б-н кирпеч йорт төзелә (архитекторы билгесез). 80 ел дәвамында бина төрле зәвыклы һәм мөмкинлекле хуҗаларның милкенә әверелә, үзгәртеп корыларга дучар була. 1908 дә әлеге йортның соңгы хуҗасы Н.М.Журавлёв варислары аны шәһәрнең сәүдәгәрләр җәмгыятенә тапшыра. Бина реконструкцияләнә һәм Сәүдәгәрләр җыены ихтыяҗларына яраклаштырыла; анда сәхнәле тамаша залы, бию залы (ак зал), ресторан (имән зал) барлыкка килә. С.җ.б. хәзерге К.Нәҗми һәм А.Островский урамнары кисешкән җирдә урнашкан, почмагындагы эркер-балкон аңа үзенчәлекле төс биреп тора. Фасадлары ахыргы чор эклектика стилендә бизәлгән. 1930 еллар башында шундагы Яшь тамашачылар театры бинасына икенче тапкыр реконструкция үткәрелә, зур сәхнә тартмасы төзелә, тәрәзәләрнең бер өлеше томалап куела, фасадлардагы күпертмә бизәкләр кубарып алына.

1995 елгы зур янгын вакытында театрның тамаша залы янгач, бина яңадан торгызыла һәм элекке хәленә кайтарыла (арх. К.И.Мусина проекты). Элекке С.җ.б.ның фасадлары һәм интерьерлары кабаттан торгызыла. Баштагы бинага балконы һәм парадный ишеге, вестибюле, флюгерлы һәм сәгатьле, гөмбәзе булган күрше йорт тоташтырыла. Ишегалдындагы корылмаларның өскормасында театр цехлары һәм гримёр бүлмәләре урнаша. 2001 елның гыйнварында реконструкциядән соң театр бинасы яңадан ачыла.

*Х.Г.Надыйрова.*

**СӘҮДӘГӘРЛӘ́Р КЛУБЫ́**, Казандагы эшлекле очрашулар һәм ял урыны. 1861 елның 9 ноябреннән 1917 нең октябренә кадәр эшли. С.к.ның 1869 ның августында расланган Уставы буенча, клуб эшчәнлегенә караган барлык мәсьәләләрне башында староста торган 7 кешелек Аксакаллар советы (клуб әгъзалары арасыннан 3 ел саен сайлана) хәл итә. С.к.нда тантаналы җыелышлар, бәйрәмнәр, хәйрия кичәләре, шәһәрнең мактаулы кунаклары б-н очрашулар уздырыла, балалар бәйрәмнәре, бию кичәләре, баллар, маскарадлар оештырыла. Клуб каршында буфет, китапханә һәм уку залы эшли. Май җитүгә, *Рус Швейцариясендә* аның җәйге йорты ачыла. 19 йөзнең ахырында С.к. өчен бина салына, анда хәзер *Казан яшь тамашачылар театры* урнашкан.

*Әд.:* С в е р д л о в а Л.М. На перекрёстке торговых путей. К., 1991.

**СӘФӘРГАЛИ́ЕВ** Камил Корбан улы (24.10.1928, Әстерхан ш. — 2.6.2000, шунда ук), нәкышьче. 1949 елда Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый (В.К.Тимофеев һәм К.Е.Максимовта укый). 1955 тә Ригада Латвия ССР СА тәмамлый (педагоглары — Э.Калныныш, В.Скулме, А.Скриде). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1956). С.нең әсәрләре бай палитрасының җиңеллеге, образларының хислелеге һәм ачыклыгы, югары проф. башкару дәрәҗәсе б-н аерылып тора. «Татар халык бәйрәме» (1955) диплом эшендә С.нең нәкышь жанрына кызыксынуы уяна, нәтиҗәдә, ул балыкчылар, бакчачылар, көтүчеләрнең көндәлек тормышы һәм хезмәтенә багышланган йөзләгән сюжетлы-тематик картиналар яза. Ил буйлап сәяхәт итә (Кырым, Балтыйк буе, Себер), Татарстанда, Мәскәүдә була; дистәләрчә пейзаж этюдлары, портрет рәсемнәре иҗат итә. Байконур космодромына барып, космонавтлар һәм галимнәр портретлары галереясын тудыра. Рәссамның колоритлы таланты Идел буе табигатенең матурлыгын чагылдырган пейзажларда ачыла. С., персонажларның психол. сыйфатларын тирәнтен өйрәнеп, ачып, портрет жанрында эшли (күпчелек балалар һәм хатын-кызлар). Әстерхан җиренең юмартлыгына, Иделдәге балык муллыгына дан җырлаган натюрмортлар авторы.

Төп әсәрләре: «Кызым портреты» (1959,1967), «Яшь натуралистлар» (1958–60), «Яр буенда», «Йөзмә пионер лагере», «Яр буенда яз» (барысы да — 1960 еллар), «Шәһәргә» (1964), «Музыкаль этюд» (1967), «Диңгез порты» (1969), «Балыкчылар натюрморты» (1969, 1980), «Академик ялда» (1976), Әстерхан балыкчыларына багышланган картиналар циклы — «Ятьмә төзәтү», «Иртә» һ.б. (1960 еллар ахыры — 1970 еллар башы); «Кабул итүдә» (1974), «Соната» (1991), «Япон айвасы», «Гурзуф бухтасы», «Кызыл каштан» (барысы да — 1992).




К.К.С ә ф ә р г а л и е в. 1. «Карбыз ашаучы кыз». Картон. Майлы буяу. 1967. Теннесси штатындагы Чаттануга шәһәренең Л.П.Клайн галереясы, АКШ; 2. «Җәтмәләр ямау» циклыннан. Картон. Майлы буяу. 1969. П.М.Догадин исем. Әстерхан картиналар галереясы.

1956 дан төрле күргәзмәләрдә, ш.и. өлкә, зона («Зур Идел», 1964–2000), күчмә («Идел буе рәссамнары», 1965), бөтенроссия («Балыкчылар көненә рәссам-маринистлар», «Диңгез хезмәтчәннәренә рәссам-маринистлар», «Балыкчыларга Россия рәссамнары», Мәскәү, 1968, 1969, 1978), татар рәссамнары әсәрләре (Әстерхан, 1992), Әстерхан рәссамнары әсәрләре (Мәскәү, 1993), халыкара («Чит ил балык сәнәгате-80», Мәскәү, 1980; «Арколь» галереясы, Париж, Франция, 1992, 1993) күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Әстерханда 1992 (Р.У.Мифтахетдинов һәм З.К.Сәфәргалиев б-н бергә), 2000, 2002 дә (вафатыннан соң) уздырыла.

С.нең әсәрләре Рус музеенда (С.-Петербург), П.М.Догадин исем. Әстерхан картиналар галереясында, Әстерхан тарих-архит-ра музей-саклаулыгында, Кристи галереяларында (Лондон, Бөекбритания), Доган (Нью-Йорк ш., АКШ), Елена Кохан (Скотсдейл ш., АКШ), Печ шәһәрендәге Сәнгать музее (Венгрия) һ.б.да, чит илләрдәге шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Художники Астрахани: Астрахань. 1998.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**СӘФӘРГАЛИ́ЕВ** (Шәрифуллин) Мөхәммәт (Мөхәммәтгали Сәфәргали) Гариф улы (2.1.1906, Самара губ., Бөгелмә өязе Мөэмин-Каратай а. — 31.12.1970, Саранск ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1963), проф. (1964). Мәскәү ун-ты профессоры С.В.*Бахрушин* шәкерте. Башлангыч белемне Бөгелмә өязенең Зәй-Каратай авылы мәдрәсәсендә алган дип фаразлана. Мәдрәсәдә җәдитчеләр — бертуган Туйкиннар укыта. 1921–22 еллардагы ачлык вакытында әтисенең бертуганы аны Төркестанга алып китә, анда С. Шәрифуллин фамилиясен С.кә алмаштыра. 1920 елларның 2 нче яртысында Төрки-татар мәгариф ин-тында (Ташкент) укый. 1932 дә Урта Азия ун-тының шәрекъ ф-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук, СССР тарихы кафедрасында эшли (1935 кә кадәр). 1939 дан Саранск пед. ин-тының СССР тарихы каф. мөдире, 1941 дән тарих ф-ты деканы. С.нең беренче басылган хезмәтләреннән берсе — «Документларда һәм материалларда Татарстан тарихы» («История Татарии в документах и материалах», 1937) җыентыгына рецензиясе Мәскәүдә чыга торган «Историк-марксист» ж-лында (1938, № 3) дөнья күрә. С.нең беренче зур фәнни хезмәте — 16 йөз Нугай Урдасы тарихы буенча тикшеренүе. С.нең «Алтын Урданың таркалуы» («Распад Золотой Орды», Саранск, 1960) дип аталган төп фәнни хезмәтендә 13–14 йөзләрдә Алтын Урданың оешу, күтәрелү, үсеш этаплары, аерым ханлыкларга таркалу тарихы яктыртыла. Галим фикеренчә, Алтын Урданың көчсезләнүенең төп сәбәпләреннән берсе — дәүләтнең икътисади нигезе, ягъни Дәште Кыпчак аша узган халыкара сәүдә мөнәсәбәтләренең җимерелүе. С. Алтын Урданың Казан татарлары килеп чыгышына һәм аларның дәүләтчелеге формалашуына тәэсире турындагы мәсьәләне дә күтәрә, Казан ханлыгын Алтын Урданың варисы дип саный. Галим Алтын Урда ханнары идарә иткән елларның хронологиясен һәм аларның шәҗәрәсен ачыклауга зур өлеш кертә. Хезмәтләренең бер өлеше мордва татарлары һәм мордва-татар мөнәсәбәтләре тарихына багышлана. С. мордва җирләренең Россиягә кушылуына Мәскәү һәм Казанның озак вакыт бер-берсенә каршы торуы йогынты ясаган дип исәпли, ул бу каршылыкны Рус дәүләте һәм Алтын Урданың үзара тәэсир итешүләре кысаларында карый. С. — Мордва Республикасында тарих фәненә нигез салучыларның берсе, аның шәкертләре арасында Н.Ф.Мокшин, Н.М.Арсеньев, В.А.Юрченков һ.б. бар. «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә. 1990 еллар уртасыннан Саранск шәһәрендә даими рәвештә Сәфәргалиев укулары уздырыла.

Х е з м.: Ногайская Орда во второй половине XVI в. // Сб. науч. работ Морд. пед. ин-та. Саранск, 1949; Заметки об Астраханском ханстве // Сб. статей преподавателей Морд. пед. ин-та. Саранск, 1951; Заметки о буртасах // Зап. Морд. НИИ языка, лит-ры, истории и экономики. 1951. Вып. 13; Один из спорных вопросов истории Татарии // Вопр. истории. 1951. № 7; Народы Поволжья и Приуралья в XIV–XV вв. // Очерки истории СССР: Период феодализма IX–XV вв. В 2 ч. М., 1953; К истории татарского населения МАССР // Тр. Морд. НИИ языка, лит-ры, истории и экономики. 1963. Вып. 24; Мордовско-татарские отношения // Этногенез мордовского народа. Саранск, 1965.

*Әд.:* Н а б и е в Р.Ф. Магомед Гарифович Сафаргалиев как историк Золотой Орды // Материалы 6 Сафаргалиевских науч. чтений. Саранск, 2000; ш у л у к. М.Г.Сафаргалиев: неизвестные страницы биографии // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2000. № 1/2.

**СӘФӘРГАЛИ́ЕВ** Рәхим Ситдыйк улы (1904, Жаркент ш., Кытай — 15.11.1970, Алма-Ата), җәмәгать эшлеклесе, шагыйрь. Голҗа шәһәрендә (Кытай) мәдрәсә тәмамлый. 1944–45 елларда «Азат Шәркый Төркестан» г-тасы әдәби хезмәткәре; Голҗаның татарлар вакыфы, мәдәни-агарту җәмгыяте әгъзасы. Туган як турында лирик шигырьләр авторы.

Х е з м.: Туган як җырлары. К., 1987.

*Әд.:* Т у ф а н Х. Туган илгә кайткан шигырьләр // Казан утлары. 1964. № 4.


*М.Г.Госманов.*

**СӘФӘРГАЛИ́ЕВ** Сәгыйть Мингали улы (6.2.1939, Алма-Ата), биналар һәм корылмаларның сейсмик чыдамлыгы өлкәсендәге галим, техн. фән. канд. (1971). 1962 елда Казакъ тау-металлургия ин-тын (хәзер Казакъ милли техн. ун-ты) тәмамлаганнан соң, Казакъстан Респ-касының төзелеш оешмаларында, фәнни-тикшеренү ин-тларында һәм югары уку йортларында эшли. 1996–2005 елларда Алма-Ата шәһәр идарәсендә гадәттән тыш хәлләрне булдырмау (1996–98), сейсмик чыдамлык һәм халыкара хезмәттәшлек фәнни-техник программалары (1998–2000) бүлекләре башлыгы; 2004 елдан координация-аналитика бүлегенең баш белгече. 2005 тән Казакъ милли-технол. ун-тында. Хезмәтләре төзелеш конструкцияләренең сейсмик чыдамлыгына карый; «Тотып торучы стеналарның сейсмик чыдамлыгы» («Сейсмостойкость зданий с несущими кирпичными стенами» (А.-А., 1988) китабы автордашы. 1992 елда бу хезмәт кытай теленә тәрҗемә ителә (Цзычун ш., Сычуань провинциясе, Кытай). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сейсмостойкость каменных (кирпичных) зданий. А.-А., 1991 (автордаш).

*Әд.:* Казахстан: Нац. энцикл. Алматы, 2006. Т. 4.

**СӘФӘРГА́ЛИН** Әсхәт Газизулла улы (8.8.1922, Минзәлә кантоны Иске Кормаш а. – 26.8.1975, Украина ССР, Харьков ш.), нәкышьче, график, Украина ССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1971). 1938 дә Казан сәнгать уч-щесенә укырга керә. 1941–45 тә Совет Армиясендә, Бөек Ватан сугышында катнаша. 1953 тә Харьков сәнгать ин-тын тәмамлый. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1960). С. — нәкышь сәнгатендә совет реалистик мәктәбенең күренекле вәкиле, сюжетлы-тематик картиналар иҗат иткән иң зур осталарның берсе. Аның әсәрләренә образларның монументальлеге, күтәренкелеге, лирик романтика хас. Аның сугышка («Шәфкать туташы», 1965; «Язгы сулар», 1971), авыл кешеләренең көндәлек хезмәтенә («Икмәкләр өлгерде» диплом эше, 1953; «Хат», 1957; «Уңыш», 1962; «Май яңгыры», 1967; «Хезмәт семестры», 1968; «Сыер савучылар», 1971) багышланып масштаблы цикл тудырган жанрлы картина, этюдлары һәм график рәсемнәре киң танылa. Персонажлары — С. тарафыннан гомумиләштерелгән образ-



Ә.Г. С ә ф ә р г а л и н. «Язгы сулар». 1971. Харьков сәнгать музее.



Ә.Г. С ә ф ә р г а л и н. «Яр буенда». 1971. Киевтагы «Вернисаж» галереясы.

ларда әхлак һәм рух чисталыгы б-н гәүдәләндерелгән Харьков тирәсе авыллары халкы («Дуңгыз караучылар», 1963; «Ахирәтләр», 1966; «Кое янында», 1967). Пейзажларда һәм пейзажлы фоннарда тәкъдим ителгән пленэр нәкышь махсус яктылык — һава мохитен, яктылык һәм кояш юмартлыгын тудырган иҗат фактурасы б-н аерылып тора («Көймә», 1963; «Урман паркы», 1973; «Югары вольтлы линия (Шебелинка)», 1975). 1970 еллар картиналарында хезмәт темасы б-н бергә авыл кешеләренең көндәлек тормышы да чагыла («Егетләр», «Туй» — икесе дә 1970; «Таганнар», 1974). С. иҗатында портрет жанры рухи кичерешләр һәм нечкә лиризм б-н сугарылган хатын-кыз образларында ачыла («Рәссам хатыны Е.И.Шевченко-Соханева портреты», 1956; «Студентлар язы», 1961; «Буйлы блузка кигән кыз портреты», 1969 һ.б.). Күп кенә картиналарга этюд һәм эскизлары камил портрет («Кызыл киемле хатын», 1969; «Ак яулыклы кыз», 1971) яки пейзаж («Кое», 1967; «Көмеш тирәкләр», 1972) булып кабул ителә. С.нең станлы графикасы еш кына нәкышь картиналарына өстәп карандаш, күмер б-н ясалган күпсанлы рәсемнәрендә тәкъдим ителә («Автомат тоткан кыз», 1965; «Кыз бала башы», 1971).

Респ-ка — «Совет Украинасы» (Мәскәү, Киев, 1960), бөтенсоюз — «Октябрьнең 40 еллыгы» (Мәскәү, 1957), «Тынычлык сагында» (Мәскәү, 1965), «Хезмәткә дан» (Мәскәү, 1976) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Харьковта уздырыла: 1954, 1977 (вафатыннан соң).

Әсәрләре Дәүләт сынлы сәнгать музеенда (Киев), Львов шәһәренең Украина сәнгате музеенда, Харьков, Донецк, Запорожье, Севастополь һ.б. сәнгать музейларында, ш.у. С. гаиләсенең шәхси тупланмасында саклана.

*Әд.:* Заслуженный деятель искусств УССР Асхат Сафаргалин: Каталог выставки. Хар., 1977; Ч е р н о в а М. Щедрість серця художника // Містецтво. 1967. № 3; Словник художників України. Киев, 1973.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**СӘФӘРИ́ЕВ** Мәгъфур Сафа улы (25.5.1940, Биектау р-ны Ташлы Кавал а.), очкыч аппаратлар һәм корабльләрнең төзелеш механикасы ныклыгы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1997), проф. (2001), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2007). 1962 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, очкыч аппаратларның төзелеш механикасы каф. профессоры (1997 дән). Хезмәтләре очкыч аппаратлар, экранопланнар һәм тиз йөрешле судноларда төп өслекләрнең ныклыгын исәпләү алымнарына карый. С. тәкъдим иткән алымнар су асты канатлы корабль конструкцияләренең ныклыгын исәпләүдә, аэрокосмик һәм судно-лар төзү пр-тиеләрендә проект эшләрендә кулланыла. Казан авиация ин-ты тарихы, авиация фәне һәм аэрокосмос техникасы буенча монографияләр авторы.

Х е з м.: Расчёт крыльевых устройств на прочность. К., 1975; Теория упругости. К., 1979; Казанский государственный технический университет им. А.Н.Туполева: Люди и вехи истории. К., 2002 (автордаш); Аэрокосмический комплекс Казани. К., 2007.


Ә.Ә. Сәфәров.

**СӘФӘ́РОВ** Әсгать Әхмәт улы (20.10.1961, Тукай р-ны Яңа Шимбер а.), полиция генерал-лейтенанты (2011; 2000 нән милиция генерал-лейтенанты), ТРның атказ. эчке эшләр органнары хезмәткәре (2001). Казан ун-тын (1984), РФ Федераль Куркынычсызлык хезмәте академиясен (Мәскәү, 1999) тәмамлый. 1984–87 елларда Казанның Совет р-ны халык депутатлары советы башкарма ком-тының эчке эшләр бүлеге тикшерүчесе. 1987–91 дә ТАССР МС өлкән референты, инструкторы. 1991–95 тә ТР Президенты ярдәмчесе. Бер үк вакытта, 1992–95 тә, ТР Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Милиция махсус хезмәте идарәсе башлыгы. 1995–98 дә РФ Федераль саклау хезмәте подразделениесе башлыгы. 1998–2012 дә ТР эчке эшләр министры, 2012–13 тә ТР Премьер-министры урынбасары, 2013 тән — ТР Президенты Аппараты җитәкчесе. Хокук саклау темасына караган хезмәтләр авторы. 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», Батырлык (2 тапкыр), Почёт, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Терроризм: История и современность. К., 2002 (автордаш); Основы борьбы с террористической преступностью: Учеб. пособие. К., 2003 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**СӘФӘ́РОВ** Марс Гыйләҗ улы (18.4.1937, БАССРның Эстәрлебаш р-ны Айдарәли а.), химик-органик, химия фән. д-ры (1980), проф. (1981), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1986). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), шунда ук эшли. 1980 елдан Башкорт ун-тының органик химия каф. мөдире. Хезмәтләре кислородлы гетероциклик кушылмаларга карый. С. иярешле Принс реакциясен ача. Олефиннар б-н альдегидлар реакциясе нигезендә 1,3-диоксаннар, пиран һәм фуран структураларын синтезлауның нәтиҗәле алымнарын эшли. Каучук һәм биологик актив матдәләр җитештерү өчен сызыкча һәм циклик мономерлар табу ысулларын тәкъдим итә һәм халык хуҗалыгына кертә. Уйлап табуга 100 дән артык авторлык таныклыгы бар. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Механизм реакций ацеталей. М., 1987; Люди и диоксины. М., 2000.

**СӘФӘ́РОВ** Миңназыйм Мәүлет улы (9.5.1961, Чуаш АССРның Батыр р-ны Татар Согыты а.), журналист. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1983), «Татарстан яшьләре» г-тасында: хәбәрче, өлкән хәбәрче, бүлек мөдире, җаваплы сәркәтип, баш мөхәррир урынбасары булып эшли. 2003 тән *«Ватаным Татарстан»* г-тасында баш мөхәррир. Бер үк вакытта, 1990 нан, Казан ун-тында укыта. Мәкаләләренең төп тематикасы — Татарстан Респ-касындагы иҗтимагый сәяси хәл, татар авыллары тормышы, яшүсмерләр арасындагы җинаятьчелек, яшьләрне әхлакый тәрбияләү. Медальләр б-н бүләкләнә.

**СӘФӘ́РОВ** Надыйр (? — 1752), Оренбург сәүдәгәре, Һиндстанга барган сәүдә кәрваны җитәкчесе. 1751 елда 5 кешедән торган кәрван (ш.и. И.*Бикмөхәммәтов*, әлеге сәфәр турындагы язмаларның авторы) Оренбургтан Бохарага юл тота. Анда Россия хакимияте тарафыннан дипломатик максат б-н Һиндстанга барырга дигән күрсәтмә алына. С. җитәкчелегендә кәрван Басра шәһәренә (Гыйрак) бара, аннан диңгез аша Сурат шәһәренә (Һиндстан) килеп җитә. Шунда кәрванга диңгез юлбасарлары һөҗүм итә. Бәрелештә С. һәлак була.

*Әд.:* У с м а н о в М.А. Записки Исмаила Бекмухамедова о его путешествии в Индию // Ближний и Средний Восток: История. Экономика. М., 1967.

**СӘФӘ́РОВ** Рәфкать Хәбибулла улы (1.5.1933, Үзбәкстан ССРның Нәмәнган ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1984), проф. (1994). Сәмәрканд ун-тын тәмамлаганнан соң (1957), Нәмәнган пед. ин-тында эшли. 1969 дан Сәмәрканд ун-тының теоретик физика каф. мөдире, 1978 дән Үзбәкстан ФАнең Атом-төш ин-тында (Ташкент). 1991 дән Татар гуманитар-пед. ун-тында (хәзер Казан ун-ты). Хезмәтләре атом-төш физикасы өлкәсенә карый. С. әйләнүнең нәадиабатик эффектларын сурәтләү өчен төшнең әйләнү халәтләре микроскопик моделен үстерә; төшнең югары спинлы халәтләре ротацион моделенең эчке почмакча моментлы вариантын тәкъдим итә; атом төшләренең тискәре җөп халәтләрен сурәтләү өчен җөплелек буенча таркатылган һәм эчке почмакча моментлы модель эшли.

Х е з м.: О некоторых вопросах развития ядерной физики в Узбекистане // Изв. АН Узб. ССР. Сер. физ.-мат. наук. 1985. № 5 (автордаш); Комбинированная ротационная модель для описания ираст полосы с выстраиванием внутреннего углового момента // Ядерная физика. 1991. Т. 53, вып. 6; Влияние октупольных взаимодействий на поведение состояний отрицательной чётности при малых спинах // Ядерная физика. 2006. Т. 69, вып. 12 (автордаш); Физика атомного ядра и элементарных частиц. К., 2008.

**СӘФӘ́РОВЛАР**, татар морзалары нәселе. 19 йөздә — 20 йөз башында Тамбов губернасының (хәзер Рязань өлкәсе) Елатьма өязе Әҗе авылында яшиләр. 18 йөз башында йомышлы татарлар С. Оренбург губернасының Уфа өязе Камай авылында һәм Касыйм шәһәрендә яшиләр. 19 йөзнең 1 нче яртысында С. нәселенең Оренбург губернасында яшәүче бер өлеше, кантон түрәләре буларак, морзалар катлавына күчерелә.

*Әд.:* Н о в и к о в В.А. Сборник материалов для истории уфимского дворянства. Уфа, 1879; Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

**СӘХА́ПОВ** Гаяз Җәмыйк улы (14.1.1939, Әлмәт р-ны Яңа Нәдер а.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994), техник фән. канд. (1992), ТАССРның атказ. химигы (1984), СССРның мактаулы нефтехимигы (1988). Казан химия-технол. ин-тын (1964), СССР МС каршындагы Халык хуҗалыгы академиясен (Мәскәү, 1988) тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген 1957 елда «Татнефть» берләшмәсенең «Әлкинефть» нефть промысе-

лы идарәсендә нефть чыгаручы оператор буларак башлый. 1965–97 дә «Түбәнкаманефтехим» АЖдә: участок механигы, цех башлыгы, баш инженер (1973 тән), бутил-каучук з-ды директоры (1976 дан), баш технолог (1978 дән), баш инженер (1981 дән), ЖБ ген. директоры (1985 тән), АҖ президенты, бер үк вакытта ген. директоры (1993 тән). 1997 дән «Петрокам» АҖ пр-тиесе (Түбән Кама ш.) ген. директоры, 2007 дән икътисад һәм үсеш буенча киңәшчесе; бер үк вакытта, 1995 тән, Түбән Кама химия-технол. ин-тының химия технологиясе каф. профессоры. С. җитәкчелегендә «Түбәнкаманефтехим» АЖдә стирол һәм пропилен окисе, гади полиэфирлар җитештерү, нормаль пентан, этилен окисен изомерлау буенча эре производстволар, җиңелчә актив матдәләр һ.б.ны җитештерү оештырыла. Нефть химиясе буенча хезмәтләр авторы. Уйлап табуга 21 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Дәүләт бүләге «Түбәнкаманефтехим» АЖдә бутил-каучук, пропилен оксиды һәм стирол җитештерүнең химик технологиясенең теоретик нигезләрен эшләве һәм камилләштерүе өчен бирелә. Халыкара Кол Гали бүләге лауреаты (1993). 1990–92 дә, 1992–95 тә ТССР, ТР ЮСлары депутаты, 1995–2000 дә ТР халык депутаты. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медаль, ТАССР ЮС Президиумы Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Математико-статистические методы контроля и управления технологическими процессами. К., 1998 (автордаш).

*Әд.:* Лучшие люди России. М., 2006. Ч. 1.

**СӘХА́ПОВ** Миңнәхмәт Җәмил улы (12.8.1957, Әлмәт р-ны Түбән Абдул а.), журналист, әдәбият белгече, филол. фән. д-ры (1998), проф. (2000). Казан ун-тын тәмамлый (1980). 1978 елда журналистлык эшчәнлеген «Татарстан яшьләре» г-тасында башлый. 1980–84 тә ВЛКСМның Биектау район ком-тында, «Казанпромстрой» трестының профсоюз ком-тында эшли. 1984–91 дә Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, баш мөхәррир урынбасары. 1991 дән «*Мирас*» ж-лы баш мөхәррире. Бер үк вакытта «Мирас» нәшрияты директоры (1993 тән), «*Сабыйга*» ж-лы баш мөхәррире (1994 тән), ТР мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү һәм кабат әзерләү ин-тында татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы каф. укытучысы (1999–2007 дә). Г.Исхакый, А.Гыйләҗев иҗаты, хәзерге заман әдәбияты турындагы хезмәтләре бар. М.Девятаевның «Тәмугтан качу» («Побег из ада», 1991) повестен татар теленә тәрҗемә итә. Халыкара Кол Гали исем. бүләк (1993) һәм ТР Дәүләт бүләге (2004) лауреаты.

Х е з м.: Алтын тамырлар. К., 1990; Кырыс чынбарлык. К., 1995; Тынлыкка эндәшү. К., 1995; Яңарыш хәбәрчесе. К., 2003; Татар ренессансының алтын дәвере. К., 2005; Бердәм агым. К., 2006; Вестник возрождения. К., 2001; Исхаки и золотая эпоха татарского ренессанса. К., 2002; Исхаки и татарская литература XX века. К., 2003.

*Әд.:* Минахмет Джамилович Сахапов: Биобиблиогр. учёных Рос. Федерации. К., 2004.

**СӘХА́ПОВ** Рөстәм Локман улы (28.10.1956, Казан), а.х. җитештерүен механикалаштыру өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2002), проф. (2004), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2007), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). 1979 елда Казан а.х. ин-тын (хәзер Казан аграр ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, ТР Югары уку йортлары ректорлар советының гыйльми секретаре (1991–2005), 2008 дән Казан архит-ра-төзелеш ун-тының юл төзү машиналары каф. мөдире, бер үк вакытта Транспорт корылмалары ин-тының Техник белем бирү үзәге директоры (2008 дән). Хезмәтләре АПК техникасын һәм җиһазларын төзүгә карый. С. бөртекле ашлык җитештерүнең энергия һәм ресурс саклаулы региональ технологиясен эшли (Бөтенсоюз механикалаштыру ин-ты б-н берлектә). Ул а.х. машиналары механизмнарының җитештерүчәнлеген күтәрә, энергия һәм ресурслар чыгымын киметә торган блоклы-модульле агрегатларын (Россия агросәнәгате күргәзмәләренең 7 алтын, 3 көмеш, 3 бронза медаленә лаек булалар); КБМ-10,8 ПС культиваторын; киң алымлы блоклы-модульле а.х. агрегатын (илнең 10 заводында чыгарыла һәм 31 төбәгендә кулланыла) уйлап таба. Уйлап табуга 7 патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре.

Х е з м.: Механизация ресурсосберегающего производства. К., 2000; Ресурсосберегающие культиваторы для многоукладного хозяйствования. К., 2000; Теоретические основы колебательных рабочих органов. К., 2001; Влагоаккумулирующие технологии, техника для обработки почв и использования минеральных удобрений в экстремальных условиях. М., 2014 (автордаш).

**СӘХӘБӘ́** (гарәп. صحابي — яклаучы, якындагы кешесе). Мөхәммәд пәйгамбәрнең көрәштәшләре, аның б-н якыннан аралашкан яки ислам дине өчен барган яуларда Пәйгамбәр б-н бергә катнашкан һәм мөселман гаскәренең иң ышанычлы өлешен тәшкил иткән фидакярдәшләре. Соңрак Мөхәммәд пәйгамбәрне гомерендә бер тапкыр, хәтта сабый чакларында күргән кешеләрне дә С. дип атый башлыйлар. Ислам тарихында С.нең аеруча әһәмияткә ия булулары пәйгамбәр вафатыннан соң аның тәгълиматларын күмәкләшеп саклаулары б-н бәйле. Исламда әхлакый-хокукый тәгълиматның иң мөһим өлешен тәшкил итүче Сөннә Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышын һәм кылган эшләрен, холкын бәян иткән хикәяләрдән (хәдисләрдән) һәм С.нең сүзләреннән тора. С.не хөрмәтләү аларның каберләренә табыну культы барлыкка килүгә китерә. Татар тарихи риваятьләрендә Шәһри Болгарга пәйгамбәр тарафыннан җибәрелгән һәм Айдар ханны, аның даирәсен мөселман диненә күндергән өч С. — Зөбәер бине Тәлха, Зөбәер бине Җадга һәм Габдрахман турында истәлекләр саклана.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**СӘХӘБЕТДИ́НОВ** Җәүдәт Мирсәяф улы (29.9.1941, Бөгелмә ш. — 30.10.2006, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1997), проф. (2000). 1964 елда Казан ун-тын тәмамлый, Казан авиация ин-тында эшли (1965 тән). 1967–96 да СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында, хисаплау газодинамикасы лаб-ясе мөдире (1985 тән); 1997 дән Казан энергетика ун-тында, җылылык техникасының теоретик нигезләре каф. мөдире (2001 дән). Хезмәтләре катнашманың өч үлчәнешле газ динамикасы мәсьәләләрен чишү алымнарына, гомоген газ тирәлегендә нәстационар процессларга, ярыклар таралу проблемаларына карый. С. өч үлчәнешле чикләнгән челтәрләрне тизләтеп генерацияләү методикасын эшли, эчке яну двигательләрен исәпләү буенча программалар комплексы тәкъдим итә. СССР ФАнең М.В.Келдыш исем. медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Анализ дискретных моделей движения точки. К., 1995; Математическое моделирование физико-химических процессов в каналах энергоустановок. К., 1999; Математическое моделирование химических реакций. К., 2001.

**СӘХӘБЕТДИ́НОВ** Мәгазь Мөбәрәкша улы (8.4.1937, Ярославль өлкәсенең Волгострой ш. – 16.07.2013, Чистай ш.), спортчы, тренер (грек-рим көрәше, татар-башкорт спорт көрәше), СССРның спорт остасы (1962), РСФСРның атказ. тренеры (1992, 1978), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994). Казан пед. ин-тының физик тәрбия һәм спорт ин-тын тәмамлый (1970). Таҗикстан ССР (1960–65), РСФСР һәм СССР халыкларының авыл спартакиадалары (1966) чемпионы. 1962–65 елларда Респ-ка югары спорт осталыгы мәктәбендә тренер-укытучы (Дүшәнбе ш.). 1966–70 тә Чистай а.х. техникумында физик тәрбия укытучысы. 1970–76 да «Урожай» ирекле спорт җәмгыятенең Татарстан өлкә советы тренеры, 1976–78 дә югары спорт осталыгы мәктәбендә тренер. 1978– 2004 тә Казан вет. медицинасы академиясендә, физик тәрбия каф. мөдире (1996 га кадәр), каф. профессоры (1996 дан). Татар-башкорт спорт көрәше буенча кагыйдәләр, программалар, дәреслекләр авторы. 1972–78 дә татар-башкорт көрәше буенча ТАССР җыелма командасы тренеры, 1980 дә Мәскәүдәге Олимпия уеннарына Дания җыелма командасын әзерләүдә катнаша. Грек-рим һәм татар-башкорт көрәше буенча якынча 40 спорт остасы әзерли. Шәкертләре арасында — А.А.*Бозин*. 2005 тән ТРда атказ. тренер А.Шәйхетдинов призына Бөтенроссия турнирлары уздырыла. ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**СӘХӘБЕТДИ́НОВ** Риф Рәис улы (9.12.1955, Уфа ш.), РФ Герое (27.4.2001), авиация генерал-майоры (2003). Сызрань Югары хәрби авиация уч-щесен (1977), Ю.А.Гагарин исем. Хәрби-һава академиясен (Мәскәү өлкәсенең Монино штп, 1988) тәмамлый. 1973 елдан СССР Кораллы көчләрендә. Монголиядә, Карпат буе һәм Төркестан хәрби округларында, Гаскәрләрнең көнбатыш төркемендә, Мәскәү хәрби округында, Таҗикстан, Төньяк Кавказ һәм Ленинград хәрби округларында хезмәт итә. Әфганстан Демократик Респ-касында барган сугыш хәрәкәтләрендә совет гаскәрләренең чикләнгән контингенты составында, Таҗикстанда тынычлык урнаштыру миссиясендә, Төньяк Кавказда террорчылыкка каршы операциядә катнаша. Төньяк Кавказ регионындагы махсус операция барышында законсыз оешкан кораллы төркемнәрне юкка чыгаруда күрсәткән ба-



Р.Р. Сәхәбетдинов.



Р.Ә. Сәхәбиев.

тырлыклары өчен (237 уңышлы хәрби очыш) Герой исеме бирелә. 2003–06 да — Хәрби-Һава көчләре һәм Һава һөҗүменнән саклану 6 нчы армиясенең авиация командиры урынбасары — авиация башлыгы С.-Петербург). 2007 дән запаста. 2008 дән Башкортстан Респ-касының С.-Петербургтагы вәкиллеге башлыгы. Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Коралллы көчләрендә Ватанга хезмәте өчен», Батырлык орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* И в а н о в А.А. Герои Российской Федерации — Россия Федерациясе геройлары. К., 2012. 121–124 б.

**СӘХӘБЕТДИ́НОВ** Рифхәт Зиннур улы (21.9.1955, Сарман р-ны Мортыштамак а.), нефтьче, техник фән. д-ры (2001), проф. (2010), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1977), Химия һәм төзелеш машиналары фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү өлкәсенең Загорск ш.) эшли. 1980 елдан ТатНИПИнефтьтә, директор (2014). Уйлап табуга 30 дан артык авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге лауреаты (1990). Дәүләт бүләге ТР нефть промыселларында энергия ресурсларын саклау технологияләрен эшләү һәм сәнәгать күләмендә кулланышка кертүдәге казанышлары өчен бирелә.

**СӘХӘБЕТДИ́НОВ** Юрий Ефимович (22.2.1944, Бондюг штп, хәзер Менделеев ш.), табиб, бальнеолог, ТР һәм РФнең атказ. табибе (1993, 1996). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1968), Менделеев үзәк район хастаханәсенең баш табибе булып эшли. 1974 елдан — «Иж минераль сулары» («Ижминводы») курорты, 1979 дан — Апастагы «Россия энҗесе» («Жемчужина России»), 1982 дән «Казан» («Казанский») санаторийлары баш табибе. 1990 нан «Татарстанкурорт» берләшмәсе ген. директоры. 2004–06 елларда Россия милли курортлар ассоциациясенең Идел буе округы баш табибе. 2006–12 дә ТРның Олимпия резервы спортчылары өчен мед.-тернәкләндерү үзәге баш табибе. Фәнни тикшеренүләре курортология өлкәсенә карый. «Санаторий-курорт оешмалары шартларында йөкле хатыннарның сәламәтлеген яхшыртуның яңа системасы» хезмәте өчен ТР Дәүләт бүләге бирелә (1996). Бөтенроссия «Ел менеджеры» конкурсы җиңүчесе (2001). Медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: «Ижминводы — Шифалы Су» — старейший курорт Татарстана. К., 2001 (автордаш).

**СӘХӘБИ́ЕВ** Рафаил Әхәт улы (8.7.1951, Түбән Кама р-ны Шәңгәлче а.), җырчы (баритон), педагог, ТАССРның халык артисты (1987). 1976 елда Казан консерваториясен тәмамлаганнан соң, Татар опера һәм балет театры солисты. 30 дан артык партия башкара: Фигаро («Севилья чәчтарашы», Дж. Россини), Валентин («Фауст», Ш.Гуно), Генрих Айзенштайн, Кизү («Ярканат», «Төрмә кизүе», И.Штраус), Евгений Онегин (шул исем. әсәр буенча, П.Чайковский), Мизгирь («Кар кызы», Н.Римский-Корсаков), Вафа («Башмагым», Җ.Фәйзи), Хан, Канзафаров («Алтынчәч», «Муса Җәлил», Н.Җиһанов), Ислам («Җиһангир», Р.Гобәйдуллин), Мулла («Кара йөзләр», Б.Мөлеков). 1974 тән концерт эшчәнлеге алып бара, телевидение һәм радиодан чыгышлар ясый. Репертуарында илебез һәм чит ил композиторларының опера әсәрләре, камера әсәрләре, татар халык һәм эстрада җырлары бар. Истә калырлык тембрлы, киң диапазонлы баритон тавышка ия. 1997 дән Казан консерваториясенең муз. театр кафедрасында укыта.

*Әд.:* З ә й д у л л а Р. Сәхәбинең сәхабәлеге // Идел. 2000. № 1; Г а л и е в М. Иде... Иде дисәм, кичерерсез мине // Сәхнә. 2004. № 6.

**СӘХӘБИ́ЕВА-БИ́ГИЧЕВА** Зөһрә Котдус кызы (27.4.1951, Ворошилов р-ны, хәзер Сарман р-ны Салих-Тукай а.), җырчы, педагог, ТАССРның халык артисты (1984). Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (1983). Х.А.*Бигичев* хатыны. 1977 елда Казан консерваториясен (З.Хисмәтуллина классы) тәмамлый. 1977 дән Татар опера һәм балет театрының концерт төркеме, 1984 тән Татар филармониясе, 1993 тән Башкорт опера һәм балет театры концерт төркеме, 1996–99 елларда «Казан» милли мәдәният үзәге каршындагы «Идел» концерт-филармония берләшмәсе солисты. 1993–99 да Казан консерваториясендә укыта. Хәзерге заманча вокал сәнгатенең иң күренекле вәкилләреннән берсе. Бай репертуарына татар һәм башкорт халык җырлары, татар композиторларының вокаль әсәрләре, Россия халыклары җырлары керә. С.-Б.ның татар халык традицияләренә нигезләнгән үзенә генә хас башкару стиле, әчкерсез, ягымлы тавышы бигрәк тә лирик әсәрләрдә сокландыра. Радио һәм телевидениедә чыгышлар ясый, Россия шәһәрләрендә, чит илләрдә (Төркия, Финляндия һ.б.) гастрольләрдә йөри. Җырлар авторы. Үзенең соло программаларының язмалары б-н дисклар чыгара, концертлар оештыра, ире Х.Бигичевның иҗади мирасын саклау һәм пропагандалауга зур көч куя. «Хәйдәр Бигичев: альбом, истәлекләр» (2010) җыентыгының төзүчесе, «Пәйгамбәрләр эзенә тамды яшьләрем...» (2012), «Җырлы гомер — гамьле гомер» (2016) китапларының авторы.

*Әд.:* З ә й н а ш е в а Г. Шифалы тавыш // Азат хатын. 1990. № 10.


*Ф.Ш.Салитова.*



З.К. Сәхәбиева-Бигичева.



З.К. Сәхәбиева-Бигичева концерт сәхнәсендә.







Р.Ә. С ә х ә б и е в: 1. Хан («Алтынчәч» операсы, Н.Җиһанов); 2. Тамир («Ерактагы кәккүк авазы», Р.Ф. Кәлимуллин); 3. Вафа («Башмагым» музыкаль комедиясе, Җ.Фәйзи; Сәрвәр ролендә – Г.А.Казанцева) рольләрендә.

**СӘХӘҮТДИ́НОВА** Роза (Руза) Хәйдәр кызы (25.6.1937, Таҗикстан ССРның Дүшәнбе ш.), композитор, БАССРның, РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1991, 1997), БРның халык артисты (1994). Уфа сәнгать уч-щесенең хор дирижёрлыгы бүлеген тәмамлый (1962), Уфа шәһәрендә музыка мәктәпләрендә укыта, Композиторлар берлеге әгъзасы (1985). Камера-инструменталь, хор әсәрләре, радио һәм телевидение, ш.у. драма спектакльләренә («Әниләр һәм бәбиләр», «Хушыгыз», Т.Миңнуллин; «Медея», Еврипид; «Югалтулар аша», И.Йомагылов һ.б.) язылган көйләр, С.Есенин, М.Цветаева, М.Кәрим, Г.Зәйнашева һ.б.ның шигырьләренә вокаль цикллар авторы. С.ның моңлы, халык җырлары традицияләренә якын булган, шул ук вакытта авторлык үзенчәлеге б-н аерылып торган җырлары (күбесенчә хәзерге башкорт шагыйрьләре шигыренә) аеруча популяр; алар концертларда, радио һәм телевидениедә яңгырый, аудио- һәм видеоязмалар рәвешендә киң тарала. Х.Бигичев, Н.Кадыйрова, З.Сәхәбиева, Х.Тимергалиева, Р.Ибраһимова кебек күп кенә танылган башкаручылар С. җырларын үзләренең репертуарларына кертәләр. БРның Салават Юлаев исем. ордены б-н бүләкләнә.

**СӘХИБГӘРӘ́ЕВ** Риф Сәет улы (23.12.1939, Ютазы р-ны Ютазы а.), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1984), проф. (1989). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1965), Көнбатыш Себер нефть геолог.-разведка фәнни-тикшеренү ин-тында (Төмән ш.) эшли. 1966 елдан «Гипротюменьнефтегаз» ин-тында лаб. башлыгы, 1972 дән Украина нефть чыгару фәнни-тикшеренү проект ин-тының Гомель бүлегендә. 1974–2004 тә Бөтенроссия нефть геол.-разведка фәнни-тикшеренү ин-тында (С.-Петербург), 1988 дән директор урынбасары, 1990 нан баш фәнни хезмәткәр (1976–78 дә Мароккода командировкада). Бер үк вакытта, 1989 дан, Петербург ун-тының геол. каф. мөдире. Хезмәтләре нефть геологиясенә карый. С. яңа күренеш — элекке су-нефтьле контактларда углеводород коллекторларының тыгызлануын ача, нефть чыганакларын эшкәртү процессында коллекторларның кайтма булмаган деформациясе барлыкка килү мөмкинлеген исбатлый.

Х е з м.: Анализ схем формирования месторождений и прогноз нефтегазоносности структур. Л., 1977; Вторичные изменения коллекторов в процессе формирования и разрушения нефтяных залежей. Л., 1989.

**СӘХИБГӘРӘ́Й ХАН** (1500, Бакчасарай ш. — 1551, шунда ук), Казан (1521–24) һәм Кырым (1532–51) ханы. *Миңлегәрәй хан* улы. 1510–11 елларда *Нурсолтан* б-н бергә Казанга һәм Мәскәүгә бара. 1521 дә Нурсолтан ярдәме б-н Казан тәхетенә утыртыла. Шул ук елда бертуганы — Кырым ханы Мөхәммәдгәрәй б-н бергә Мәскәү кенәзлегенә каршы яу оештыра; көнчыгыштан һәм көньяктан һөҗүм итүче татар гаскәрләре, Ука елгасында рус полкларын тар-мар итеп, Түбән Новгород шәһәрен алалар һәм Мәскәүне камыйлар. Мәскәүнең бөек кенәзе Василий III «элекке заманнардагыча» ясак түләү шарты б-н солых килешүе төзергә мәҗбүр була. 1523 тә С.х. боерыгы б-н Казанда рус сәүдәгәрләре тар-мар ителә, рус илчесе Ю.В.Подҗогин үтерелә. Рус гаскәрләре Казанның чик буе өлкәләренә яу б-н киләләр, форпост буларак Васильсурск кальгасына нигез салына. 1523–24 тә С.х. Төркия б-н килешү төзи, үзен солтан вассалы дип таный. 1524 тә Казан тәхетен Сафагәрәйгә калдырып, үзе Кырымга, аннан Истанбулга китә. Истанбулда Сөләйман солтан сараенда яши. 1532 дә аның булышлыгы б-н Кырым тәхетенә утыра. 1532–37 дә Бакчасарайдан куылган Исламгәрәй хан б-н сугыша. Рус дәүләтенә каршы сәясәт алып бара, Польша короле Сигизмундны яклый, Мәскәүдән Казанга дәгъва белдерүдән баш тартуын таләп итә. 1538 дә Кырым гаскәрләре төрек гаскәрләренең Молдавиягә явында катнаша. 1539 да һәм 1545 тә Кабардада һәм Чечняда сугыша. 1541 дә Мәскәүгә яу оештыра, әмма Ука елгасында рус гаскәрләре тарафыннан туктатыла. 1546–47 дә Нугай Урдасы б-н сугыша. 1551 дә Черкесиягә яу оештыра. Сөләйман солтан боерыгы б-н Кырым ханлыгы тәхетенә Дәүләтгәрәй утыртыла. Яудан кайтканнан соң, С.х. үтерелә.

*Әд.:* В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1864. Ч. 2; Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Халим Гирай. Розовый куст ханов, или История Крыма. Симферополь, 2008.

*И.Л.Измайлов.*

**СӘХИБГӘРӘ́Й ХАН ЯРЛЫГЫ́**, Казан ханы *Сәхибгәрәйнең* тарханлык ярлыгы, Казан ханлыгы чоры язма истәлеге. 1523 елның 1 гыйнварында (13 сәфәр 919 һиҗри) язылган, аксөяк Шәех Әхмәт б-н аның туганнарына бирелә. Әмирләргә, хакимнәргә, бөек сәедләргә, кадыйларга, хөрмәтле шәхесләргә, вәкилләргә, кече илчеләргә, урыннардагы түрәләргә, бакча һәм мәхкәмә түрәләренә, барча халыкка, «гомумән бөтен Казан өлкәләренә һәм бөтен патшалыкларга» мөрәҗәгать була. Документта әйтелгәнчә, Мөхәммәд улы Шәех Әхмәт, аның улы Абдал, Сәед Әхмәт, аның абыйсы Мөхәммәд улы Муса, Сәид улы Якуб, аның бертуганнары Булан һәм Нур Сәид «баш иеп сәламлиләр», элеккеге ханнар заманында тарханнар булалар. Ярлыкта аларның элеккеге хокуклары раслана, аларны, аларның байлыгын һәм «даругаларда, торакларда, юлда, өйдә» кешеләрне саклау гарантияләнә, салым, ясак, бурычлардан (ясак-калан, салыг мусамма, кулыш-култык, тамга-тартнак, хәрәҗ-хәрәҗәт, җир салымы, морҗадан салым, авыл иманасы, азык-төлек һәм фураж җыю, куна керү йөкләмәсе) азат ителүләре әйтелә. Хан боерыгын бозучыларга алдан ук кисәтү ясала: «... аларга яхшылык булмаячак». Башка ярлык аналоглары б-н чагыштырганда, текст Аллага дан җырлау б-н башлана дип фаразларга була. Расланган ярлык, гадәттә, ахырыннан башлап төргәккә төрелә. Ярлыкның башы — документның өске өлеше бозылган, шунлыктан күп кенә ярлыкларның, ш.и. С.х.я. текстының да бу өлеше югалган. Сакланган текстта 23 юл бар, кәгазьгә язылган; ике бит ябыштырылган (17,7×76 *см*). С.х.я.ның тышкы бизәлеше (тар озын төргәк) татар ханлыклары чорындагы ярлыкларга хас. Ярлык, рикъа элементларын кертеп, гадиләштерелгән дивани почеркы б-н кара кара б-н язылган. Тархан грамотасының төп нөсхәсе булуы Җүчиләр йорты *тамгасының* эзе б-н раслана. Тамга кызыл квадрат мөһердән (13,5×13,5 *см*) гыйбарәт, аның эчке ягында язулар була (башка ярлыкларда да очрый, аларда Аллаһны мактау сүзләре языла). Казан ярлыгының төп үзенчәлеге — «Аллаһтан башка алла юк, Мөхәммәд аның пәйгамбәре» гыйбарәсенең өч тапкыр кабатлануында. Уртасында, кечкенә генә турыпочмакта, өч япьле герб бар. Текстның уртасында, поляда, кызыл төстәге кечкенә генә озынча тап бар, бармак башы эзе калган дип фаразлана (тамга һәм бармак эзенең бер төстә булуы документның төп нөсхә булуына өстәмә дәлил). С.х.я.нда Алтын Урдадан (Җүчи Олысы) Казан ханлыгына дәүләт оешмалары традицияләренең күчә баруы, Казан ханлыгында канцелярия эшләренең югары дәрәҗәдә алып барылуы, анда кулланылган салым төрләре һәм социаль структура (гражданнар һәм идарә итүчеләр арасында алга киткән хокукый мөнәсәбәтләр урнаша) санап кителә. С.х.я.н беренче өйрәнүче татар археографы С.Г.*Вахиди* була. Ул ярлыкны 1912 елда Казан губернасы Мамадыш өязе Мамалай авылында крәстиян Рәхмәтулла Әхмәровтан таба (ул аны шәхси талисман буларак саклый). 1920 дә С.Г.Вахиди С.х.я.н ала һәм Академүзәк каршындагы музейга тапшыра. Өйрәнелгәннән соң, ярлык рус теленә тәрҗемә ителә һәм фәнни әйләнешкә кертелә. Ярлык ТРның Милли музеенда саклана. Ш.у.к. *Ярлыклар*.



Сәхибгәрәй хан ярлыгы. 1523. ТР Милли музее.

*Әд.:* В а х и д о в С.Г. Ярлык хана Сахиб-Гирея // Вестн. Науч. Об-ва татароведения. 1925. № 1–2; М у х а м е д ь я р о в Ш.Ф. Тарханный ярлык Казанского хана Сахиб-Гирея 1523 г. // Новое о прошлом нашей страны. М., 1967; У с м а н о в М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. К., 1979.

*И.Л.Измайлов, С.Ю.Измайлова.*

**СӘХИБГӘРӘ́Й бинé ӘХМӘ́Д** (тулы исеме Сәхибгәрәй бине Әхмәд әл-Болгари әс-Салмани) (19 йөзнең 2 нче яртысы), шагыйрь. Тәхәллүсенә караганда, чыгышы б-н Иске Сал-



Н.А.Сәхибуллин.

ман авылыннан (хәзерге Әлки р-ны). Төрек шагыйре И.Хаккыйның «Мәгърифәтнамә»сенең («Белем китабы», 1845) бер бүлегенә *назыйрә* авторы.

Ә с ә р.: Шәрхе әбъяте Ибраһим Хаккый. К., 1884.
*М.И.Әхмәтҗанов.*

**СӘХИБУ́ЛЛИН** Наил Абдулла улы (8.10.1940, Казан), астрофизик, физика-матем. фән. д-ры (1987), ТР ФА академигы (1992), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2000), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2005). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1963), шунда ук эшли, астрономия каф. мөдире (1987–2013), бер үк вакытта физика ф-ты деканы (1988–91), проф. (1988), В.П.Энгельгардт исем. астрономия обсерваториясе директоры (1991–2008). 1992–2012 елларда ТР ФАнең Физика, энергетика һәм Җир турында фәннәр бүлеге акад. секретаре. Хезмәтләре йолдызлар астрофизикасына карый. С. йолдыз спектрлары анализына локаль термодинамик тигезләнеш (ЛТТ) фаразына нигезләнмичә якын килә. С. алымы фаразларга (аксиомаларга) таянмыйча гына йолдыз атмосфераларын һәм аларның спектрларын тикшерергә, йолдыз спектры сызыкларының көчен анализларга мөмкинлек бирә, физикага күбрәк нигезләнә һәм отышлырак алым булып санала. С. традицион күзаллаулар кысаларында аңлату тапмаган астрофизик процессларны аңлата; йолдыз спектрларында яңа астрофизик күренешләрне (кайбер сызыклар эмиссияләре) алдан әйтә. Бу алым башка астрофизик объектларны: аккрецион дискларны, тышкы атмосфералары нурландырып торган куш системаларны өйрәнгәндә кулланыла; РФАнең Астрономия ин-тында (Мәскәү) һәм Украинаның Баш обсерваториясендә (Киев) файдаланыла. С. 2000 дә Төркия терр-ясендәге обсерваториядә урнаштырылган АЗТ-22 (РТТ-150) оптик телескобын төзү һәм файдалануга тапшыру буенча тикшеренүләрнең фәнни җитәкчесе була (1987 дән). Аның җитәкчелегендә күзәтүләрдән алынган мәгълүматны анализлау һәм фәндә куллану эшләре алып барыла. Халыкара астрономия берлеге (1985 тән), Евразия астрономия җәмгыяте (1990 нан) әгъзасы, Европа астрономия җәмгыяте әгъзасы һәм аңа нигез салучы (1992 дән). 2009 да РТТ-150 телескобы һәм Казан ун-тында төзелгән аппаратлар комплексы ярдәмендә актив галактикалар төшләре, гамма-балкышлар, космик рентген чыганаклары, астероидлар һәм йолдызларның нәзек спектроскопиясе өлкәсендәге тикшеренүләре өчен ТРның Дәүләт бүләге бирелә. РФАнең акад. А.А.Белопольский исем. бүләге лауреаты (1996). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Эффекты отклонений от ЛТР в атмосферах F-сверхгигантов // Астрофизика. 1985. Т. 22 (автордаш); Атмосферы, облучаемые рентгеном, и их спектры // Астрон. журн. 1996. Т. 73 (автордаш); Методы моделирования в астрофизике: В 2 т. К., 1997–2003; Наблюдения оптического послесвечения гамма-всплеска 060526 на телескопе РТТ-150 // Письма в астрон. журн. 2007. Т. 33 (автордаш).

**СӘХИ́ПОВ** Ләззәт Сәет улы (17.8.1961, Сарман р-ны Ләшәү Тамак а.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1984), «Түбәнкаманефтехим» АҖдә эшли: смена башлыгы, мастеры, цех башлыгы урынбасары, этилен з-ды җитештерү-техник бүлеге башлыгы (1999 елдан), АҖнең техник идарәсе башлыгы урынбасары (2003 тән). Уйлап табуга 17 патенты бар. Дәүләт бүләге түбән олефиннар, бутадиен һәм бензол җитештерүнең куәтен һәм нәтиҗәлелеген арттыру буенча эшләр комплексының фәнни һәм гамәли нигезләрен эшләүдә катнашуы, аларны куллануга кертүе өчен бирелә.

**СӘХЛӘБЧӘЛӘ́Р** (Orchidaceae), бер өлешле күпьеллык үләнчел үсемлекләр семьялыгы. 750 ыруг һәм якынча 35 мең төрне берләштерә, бөтен Җир шарында, башлыча, дымлы тропик урманнарда таралган. Татарстан терр-ясендә — 19 ыруг, 30 төр бар. Тамырлары еш кына бүлбесыман калын. Яфраклары чиратлашкан, бөтен, җиңсәле яки сабакны уратып алганнар. Чәчәкләре ике җенесле, дөрес булмаган формада, башак һәм чук чәчәк төркемендә. Чәчәк тирәлеге ачык, хуш исле, ике катлы, нектарлыгы һәм чыгынтысы бар. Түбәнге таҗ яфрагы («ирен» дип йөртелүче) катлаулы төзелешле, бөҗәкләр өчен «утыру мәйданы» хасил итеп, гадәттә, чәчәктән чыга. Һәрбер чәчәктә берәр серкәч. Җимеше — вак орлыклы бер оялы тартмачык. С. бик акрын, фәкать үсемлек б-н симбиоз хасил итүче билгеле бер гөмбәләр булганда гына үсәләр. Оялаш уты, каекчәчәк, иренләч ут хлорофилсыз үсемлекләр. Төертамыр, бармактамыр, төн миләүшәсе, шәрә бизлек һ.б.ның киптерелгән тамырчаларыннан медицинада кулланыла торган салеп алалар. Башмакчәчәк, иренләч ут, күке яше, листера уты һ.б. — декоратив үсемлекләр. 25 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**«СӘХНӘ́»**, рәсемле театр, эстрада журналы. 2002 елның гыйнварыннан Казанда татар телендә нәшер ителә. Оештыручылары — «Салават күпере» дәүләт учреждениесе, «Татмедиа» ААҖ (2009 дан). Башта ике айга 1 тапкыр, 2009 дан ай саен басыла. «Сәхнәдә күңел тормышы яктырак. Ул, намус кебек, безгә бирелгән. Ансыз безгә яшәү юк!» лозунгы б-н чыга. 2002 дә газета форматында басыла. Мөхәррирләре — З.Хөснетдинов, Т.Миңнуллин (2009–2012). Журнал б-н танылган театр белгечләре (И.Илялова, Д.Гыйммранова, Н.Игъламов), драматурглар (Р.Батулла, М.Гыйләҗев, Д.Салихов) хезмәттәшлек итә. Хәзерге татар сәнгате һәм эстрадасына, төрки дөньяның мәдәни тормышына багышланган язмалар дөнья күрә. Журналда — татар мәдәнияте һәм сәнгатенең күренекле вәкилләре иҗаты, тормыш юллары һәм шөгыльләре (әйтик, 2009 ның ноябрь саны М.*Сәлимҗанов* юбилеена багышлана) тасвирлана. Премьера спектакльләренә һәм концертларына рецензияләр, шоу-бизнес яңалыклары басыла. «Кыйммәтле кадр» рубрикасында татар артистлары фоторәсемнәре бирелә. Һәр елны төрки халыкларның «Нәүрүз» театр фестивале һәм Халыкара мөселман киносы фестивале киң яктыртыла.

**СӘХРӘ́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 62 *км* көньяктарак, Иж елгасыннан 3 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 82 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1926 да нигез салына. Оешкан көненнән Алабуга кантоны Салавыч волостенда. 1928 дән — Әгерҗе, 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1926 да — 64, 1938 дә — 100, 1949 да — 115, 1958 дә — 167, 1970 тә — 147, 1989 да — 96, 2002 дә — 83 кеше.

**СӘҺСӘ́Н (СУСА́Н) әр-РАСИ́** (سوسن الرسى) (? – ?), *Болгарга әл-Моктәдир илчелеге* җитәкчесе (921–23). Әл-Мутаззага бәйле кеше була. Хәлифә әл-Моктәдир б-н хакимлек өчен барган көрәш вакытында Сәһсән аңа хыянәт итә (914–15), шуның өчен хәлифә сараеннан хезмәткә алына. 921 дә Хәзәр каганлыгына каршы берләшмә төзү, хәлифәнең абруен ныгыту һәм ислам динен тагын да еракларга җәелдерү өчен Болгар дәүләтенә җибәрелгән илчелек җитәкчесе итеп билгеләнә. Үзенең аз белемлелеген һәм кыюсызлыгын сәбәп итеп, барлык эшләрне илчелек сәркәтибе Ибне Фазланга тапшыра.

*Әд.:* К о в а л е в с к и й А.П. Книга Ахмеда Ибн Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг. Хар., 1956.
*И.Л.Измайлов.*

**СӘЯ́ПОВ** Искәндәр Әгъзам улы (15.9.1934, БАССРның Борай р-ны Чишмә-Борай а. — 8.7.2008, Уфа ш.), театр рәссамы, нәкышьче, БРның атказ. рәссамы (1994). Уфа сәнгать уч-щесен (1967), Уфа сәнгать ин-тының театр декорациясе бүлеген (1978) тәмамлый. М.Н.Арсланов, Р.М.Нурмөхәмmәтов укучысы. Борай халык театры (1968–73), М.Гафу-



И.Ә.С ә я п о в. К.Тренёвның «Любовь Яровая» пьесасына декорация эскизы. Картон. Майлы буяу.

ри исем. Башкорт акад. драма театрының (1978–81) куючы рәссамы, Башкорт сәнгать фонды (1987–91), Туймазы татар драма театры (1991–98), Башкорт филармониясенең (1998–2000) баш рәссамы. 2002 дән М.В.Нестеров исем. Башкорт сәнгать музееның «Иҗат» күргәзмәләр залы мөдире. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1980).

С. милли сәхнә бизәлеше үсешенә зур өлеш кертә. Аның театр рәссамы сыйфатында эшчәнлеге 1960 елларда БАССРның Борай р-ны үзешчән коллективлары спектакльләрен бизәүдән башлана. Респ-кадагы әйдәп баручы театрларның 40 тан артык спектакльләренә: Х.Вахитның «Яшерен эзләр», Ә.Атнабаевның «Ул кайтты» (икесе дә — 1959–62), М.Фәйзинең «Галиябану», С.Җамалның



И.Ә.С ә я п о в. «Натюрморт». 1968. Картон. Майлы буяу.

«Кара розалар» (икесе дә — 1972), М.Кәримнең «Айгөл иле», Б.Лаврентьевның «Җимерелү» («Разгром») (икесе дә — 1978), К.Трепёвның «Любовь Яровая», А.Коломиецның «Туган йорт» («Отчий дом») (икесе дә — 1982) һ.б., ш.у. концерт куелышларына декорацияләр, театр һәм сәхнә фольклор костюмнары эскизлары авторы. С.ның Туймазы татар драма театрындагы иҗат эшчәнлеге аеруча уңышлы була, аның спектакльләргә ясаган декорацияләрендә драматургиянең милли үзенчәлекләре сәхнәнең образлы бизәлеше б-н табигый бергәлек барлыкка китерә: М.Фәйзинең «Ак калфак», Т.Миңнуллинның «Без бит авыл малае» (икесе дә — 1991), Г.Рәхимнең «Кәҗә белән сарык әкияте», А.Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» (икесе дә — 1992), Т.Миңнуллинның «Илгизәр + Вера» (1993), Ә.Мирзаһитовның «Гөлбакча» (1999) һ.б. С. сәхнә бизәүдә символик-метафора юнәлешендәге традицияләрне дәвам иттерә. Аның әсәрләре образның гүзәллеге-нәфислеге, тормышчанлыгы б-н аерылып тора. Станлы нәкышь һәм графика өлкәсендә С. портрет («Бозау караучы кыз», 1963; «Анам портреты», 1984; «Советлар Союзы Герое Ә.З.Закиров», 1985; «Әхәт Уразмәтов портреты», 2001; «Галимнур портреты», 2006) һәм пейзаж («Туган як киңлекләре», 1978; «Үз җиремдә» сериясе, 1978; «Агыйдел буенда», 1985) жанрларындагы лирик рухлы якты әсәрләр иҗат итә. Натюрмортлар авторы.

Респ-ка (1960 тан) — «БАССРның халык театрлары рәссамнары» (Уфа ш., 1972), «Башкортстан Республикасының сәхнә бизәүче рәссамнары» (Уфа, 2000), зона — «Социалистик Урал» (1979, 1985, 1997), бөтенсоюз — «Советская Россия» (Мәскәү, 1975) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Борай авылында (1972, 1990, 1991, 2000), Уфада (1984, 1994) уздырыла.

Әсәрләре М.В.Нестеров исем. Башкорт сәнгать музеенда, Борай авылы музеенда, БРның Кыргыз-Миякә авылындагы картиналар галереясында саклана.

*Әд.:* Искандер Саяпов: Буклет. Уфа, 1991; Выставка произведений художников сценографов Республики Башкортостан: Каталог. Уфа, 2000; Ф е н и н а Э.П. Художники Башкортостана. XX век. Уфа, 2002; М е л к о з е р о в а И. Мастер портретов и декораций // Истоки. 2009. № 9.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**СӘЯСИ́ ПА́РТИЯЛӘР**, төп максатлары җәмгыятьнең сәяси тормышында катнашу булган иҗтимагый берләшмәләр. С.п. төрле социаль төркемнәрнең сәяси мәнфәгатьләрен яктырталар, массаларның сәяси яктан оешуына булышлык итәләр, хөкүмәтнең тупланышына, идеологик доктриналарга йогынты ясарга омтылалар, дәүләт һәм муниципаль (җирле) хакимият органнарына сайлауларда, законнар чыгару эшчәнлегендә катнашалар, җәмгыятьнең сәяси элитасын формалаштыру каналларының берсе булып торалар һ.б. РФдә С.п. аларны иҗтимагый берләшмәләрнең төрле төрләреннән — хәрәкәтләр, берлекләр, ассоциацияләр, җәмгыятьләрдән аерып торучы билгеләргә ия: арадан фәкать алар гына дәүләт хакимияте органнарындагы сайланулы вазифаларга кандидатлар тәкъдим итү хокукына ия, аларның үзәкләштерелгән һәм унификацияләнгән оешкан структуралары, индивидуаль һәм теркәлүле әгъзалык тәртибе бар һ.б. С.п.нең эчке төзелеше, структура подразделениеләре арасындагы үзара мөнәсәбәтләр, партия әгъзаларының статусы уставлар б-н билгеләнә. Идеологик юнәлешләр программа, декларация, манифест, мөрәҗәгать һәм башка документларда чагылыш таба.

Хәзерге Татарстан терр-ясендә С.п. 20 йөз башларында формалаша башлый, Казанда соц. партияләрнең — РСДРП һәм Социалист-революционерлар партиясенең беренче ком-тлары барлыкка килә. РСДРП партиясе *большевиклар* һәм *меньшевикларга* аерыла. 1905–07 еллардагы рев-ция вакытында Казан губернасында либераль (к. *«Конституцион демократлар партиясе»*, *«Унҗиденче октябрь берлеге»*), монархиячел (к. *Карагруһчылар*), гомуммөселман (к. *«Иттифакъ әл-мөслимин»*) һәм башка С.п.нең ком-тлары оеша. 1917 елга кадәр, кадетлар, с.-д. һәм эсерлардан тыш, ком-тларның күбесе актив эшчәнлекләрен туктата. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң татар с.-д. С.п.: *Татар социал-демократик эшчеләр партиясе, Россия мөселман коммунистлары партиясе* һ.б. барлыкка килә. Гражданнар сугышы барышында С.п.нең күбесе таркала; РКП(б) дан башка соц. партияләр генә кала. 1923 тә барлык соц. партияләрнең эшчәнлеге тыела, яки алар үзләре ябыла, РКП(б) (к. *Советлар Союзы Коммунистлар партиясе*) монополиясе башлана. Партияләр арасында конкуренция булмау шартларында КПСС структуралары чынлыкта дәүләт хакимияте вәкаләтләрен башкаручыга әверелә. КПССның дәүләт хакимиятен тормышка ашыру монополиясе СССР Конституциясенең 6 нчы маддәсендә беркетелә (1977). Иҗтимагый тормышның либеральләшүе процессында 1980 еллар ахырында илдә күппартияле система торгызылу өчен шартлар туа, 1990 да СССР Конституциясенең 6 нчы маддәсе гамәлдән чыгарылу һәм «Иҗтимагый берләшмәләр турында» (1990) СССР Законы кабул ителүдән соң, ул юридик раслана.

РФдә С.п. эшчәнлеге РФ Конституциясе (1993), «Иҗтимагый берләшмәләр турында» (1995), «Сәяси партияләр турында» (2001) кабул ителгән федераль законнар, сайлауларга кагылышлы законнар җыелмасы һәм башка хокукый актлар б-н көйләнә. 1998 гә кадәр С.п. дәүләт хакимиятенең федераль һәм төбәк органнарына сайлауларда башка иҗтимагый берләшмәләр (хәрәкәтләр, ассоциацияләр, профсоюзлар, җәмәгать фондлары) б-н бер дәрәҗәдә катнашалар. 1998 дә «сәяси иҗтимагый берләшмә» төшенчәсе кертелгәннән соң, профсоюзлар һәм җәмәгать фондлары дәүләт хакимияте органнарына кандидатлар тәкъдим итү хокукын югалта. 2003 тән андый хокукка С.п. һәм сайлау чорында оешкан сайлау блоклары, 2005 тән фәкать С.п. генә ия була. 1990 нан С.п., эшчәнлекләренең терр. даирәсенә карап, төрле: гомумроссия, төбәк, җирле статуска ия була ала. 2003 тән РФ субъектларының яртысыннан артыгында теркәлүле төбәк бүлекчәләре булган гомумроссия С.п.е генә гамәлдә санала. Дини һәм этник юнәлештәге, ш.у. конституцион стройны көч кулланып үзгәртергә омтылучы партияләр эшчәнлегенә чик куела. 2001 дән берьюлы ике яки берничә сәяси партиядә әгъза булып тору тыела. 1990 нан гомумроссия партияләрендәге әгъзалар саны — 5 мең кешедән, 2001 дән — 10 мең кешедән, 2006 дан 50 мең кешедән ким булмаска тиеш дип билгеләнә.

РФдә 1990 еллар башында күппартияле система формалашуда ике юнәлеш күзәтелә. Бер яктан, КПССның дезинтеграция процессы бара: а) идеологик платформалар, мәс., «КПССның демократик платформасы», «КПССның марксистик платформасы» барлыкка килә; б) терр. билгеләр буенча — союздаш респ-калар компартияләренең кайберләре (Литва, Латвия, Эстония һ.б.) үзләрен КПСС тан бәйсез дип игълан итәләр. Икенче яктан, яңа С.п. төрле формаль булмаган берләшмәләр һәм төркемнәр, ш.и. сайлаучылар берләшмәләре нигезендә төзелә. Күппартияле системаның үсеш алуына беренче этәргечне альтернатив рәвештә уздырылган СССР (1989), ш.у. союздаш һәм автономияле респ-калар, өлкә советлары (1990) халык депутатларын сайлаулар бирә. Акрынлап идеологик төрлелек киңәя: соц., с.-д., либераль, милли һәм башка төрле С.п. оеша. Россия либераль-демократик партиясе, Россия

демократик партиясе, РФ с.-д. партиясе, РФ респ-ка партиясе (барысы да — 1990), «Ирекле Россия» («Свободная Россия») халык партиясе (1991) аеруча киң таныла. ГКЧП режимы җиңелгәннән соң (19–21 авг., 1991), КПССның эшчәнлегенә чик куела. Әлеге вакыйга «коммунистик күппартиялелек» исеме алган, төрле соц. һәм коммунистик партияләрнең киң спектрын барлыкка китергән күренешкә нигез сала. 1991 дә Хезмәт иярәре соц. партиясе, Россия коммунистик эшчеләр партиясе, Бөтенсоюз коммунистлар (большевиклар) партиясе төзелә. КПСС эшчәнлеген тыю бетерелгәннән соң, коммунистик партияләрнең иң күпсанлысы — РФ Коммунистлар партиясе оешу (1993) өчен шартлар туа. Россия аграр партиясе дә шул вакытта төзелә (1993). РФдә күппартияле система барлыкка килүгә һәм аның эволюциясенә Дәүләт Думасына сайлаулар (1993, 1995, 1999, 2003, 2007), ш.у. партия (2001 дән) һәм сайлау (2005 тән) системаларындагы реформалар зур йогынты ясый. Россия С.п.енең күпчелеге: а) сайлау блоклары һәм кайбер очракларда баштарак партиядән тыш оешмалар статусында булган берләшмәләр нигезендә (мәс., «Яблоко» Россия берләшкән демократик партиясе 1995 тә төзелә, партия статусы — 2001 дән; «Уң көчләр берлеге» («Союз правых «сил») — 2000 дә, партия статусы — 2001 дән; «Бердәмлек» («Единство») — 2000 дә, партия статусы — 2001 дән); б) берничә партия һәм хәрәкәтнең берләшүе нигезендә (мәс., «Бердәм Россия» («Единая Россия»), 2001; «Россия патриотлары» («Патриоты России»), 2005; «Гадел Россия: Ватан / Пенсионерлар / Тормыш» («Справедливая Россия: Родина / Пенсионеры / Жизнь», 2006); в) хәрәкәтләрнең үзгәртеп корылуы нигезендә (ш.и. РФ халык партиясе, 2001; «Эшмәкәрлекне үстерү» («Развитие предпринимательства», 2001) барлыкка килә. Россия күләмендә 1993 тә — 36, 1998 дә — 95, 2005 тә — 37, 2008 дә 15 гомумроссия С.п.е теркәлә. 2007 дән Дәүләт Думасында 4 партия фракциясе исәпләнә: «Бердәм Россия», РФ коммунистлар партиясе, Россия либераль-демократик партиясе, «Гадел Россия: Ватан / Пенсионерлар / Тормыш».

1990 елларда Татарстанда күппартияле системаның гомумроссия моделеннән аермалы үз төбәк моделе формалаша. Аның үзенчәлеге татар милли партияләрен: федералистик (Мәскәүгә йөз тоткан) партияләрне; коммунистик партияләрне; урталыктагы (центристик) партияләрне эченә алган төбәк С.п.е өстенлек итү б-н билгеләнә. РФнең партия-сәяси системасын унификацияләү процессында, 2001–03 ләрдә, әлеге төбәк үзенчәлекләре юкка чыга. 1990 елларда Татарстандагы иң билгеле партияләр булып радикаль юнәлешле *Татар милли азатлык партиясе «Иттифакъ»* (1990) һәм уртачыл караштагы Татарстан респ-ка партиясе (1992) санала. Аларга РФнең хакимият һәм сәяси структураларына йөз тоткан, респ-ка суверенитетына тискәре мөнәсәбәттә булган федералистик партияләр каршы тора. Бу төркемдә күпчелеге гомумроссия партияләренең бүлекчәләрендә торган либераль һәм с.-д. доктриналар тарафдарлары өстенлек итә. 1990 елларда Россия демократик партиясе, РФ с.-д. партиясе, РФ респ-ка партиясе, «Ирекле Россия» халык партиясе, «Россия демократик сайлавы» («Демократический выбор России»), «Яблоко» партияләренең бүлекчәләре киң таныла. 1991–92 дә коммунистик хәрәкәт — ТР коммунистлары оешмасы (к. *Россия Федерациясе коммунистлар партиясенең Татарстан региональ бүлеге*) торгызыла. 1993 тә, совет хакимиятенең вәкаләтләре тукталганнан соң, респ-ка җитәкчелегенең мәнфәгатьләрен чагылдырган, с.-д. кыйммәтләргә юнәлеш тоткан беренче партия — Татарстанның «Бердәмлек һәм прогресс» («Единство и прогресс») партиясе төзелә. Рус милли агымнары тарафдарларының йогынтысы гаять чикле була, чөнки респ-каның рус милләтле халкының төп массасы мәнфәгатьләрен де-факто федералистик юнәлештәге партияләр чагылдыра. Россия либераль-демократик партиясе, «Россия гомумхалык берлеге» («Российский общенародный союз») партиясе, Руслар партиясе һәм башка партияләрнең бүлекчәләре шушы ук юнәлештә эш алып бара. РФнең «Сәяси партияләр турында»гы законы (2001) кабул ителгәннән соң, күп кенә төбәк С.п.енең эшчәнлеге туктала; аларга алмашка гомумроссия С.п.енең бүлекчәләре килә: «Бердәм Россия», «Уң көчләр берлеге», РФ халык партиясе бүлекчәләре (барысы да — 2001), Россия тормыш партиясе бүлекчәсе (2002), «Россия патриотлары» партиясе бүлекчәсе (2005) һ.б. 2015 нең февраленә Татарстанда 66 партиянең төбәк бүлекчәләре теркәлгән. Ш.у.к. *Татарстанда иҗтимагый-сәяси оешмалар һәм хәрәкәтләр*.

*Әд.:* Исхаков Д.М. Суверенный Татарстан: Документы. Материалы. Хроника: В 3 т. М., 1998; Терентьева И.В., Беляков Р.Ю., Сафаров М.Ф. Республика Татарстан: Политические партии, движения, лидеры: В 2 кн. К., 2001–03; Сафаров М. Реформа партийной системы в России сквозь призму демократии и федерализма // Казанский федералист. 2006. № 1/2.

*М.Ф.Сәфәров.*

**СӘЯ́Х** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 14 *км* көнбатыштарак, Игәнә елгасы буенда. 2010 елда 7 кеше (татарлар) яши. 1920 еллар ахырында нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чаллы кантоны Сарман волостенда. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1938 дә — 196, 1949 да — 152, 1958 дә — 122, 1970 тә — 87, 1979 да — 59, 1989 да — 17, 2002 дә — 7 кеше.

**СӘЯХӘТНАМӘ́** (гарәп-фарсы. سياحتنامه — сәяхәт турында китап), сәяхәттә күргәннәрне тасвирлаган көндәлекләр, әдәби язмалар һәм сәяхәткә бәйле мемуар характерындагы әсәрләр. Күбрәк проза б-н, сирәгрәк шигъри формада иҗат ителә. С.дә, гадәттә, автор турында, аны юлга чыгарга мәҗбүр иткән сәбәпләр, җирле халыкның икътисады, мәдәнияте, көнкүреше, холкы, этнографиясе турында тарихи-геогр. мәгълүматлар, авторның шәхси фикерләре китерелә; ахырдан ватанга кайтуы тасвирлана. Татар әдәбиятында беренче С.ләр 18 йөздә күренә башлый («Исмәгыйль ага сәяхәте», 1751; «Мөхәммәдәмин сәяхәтнамәсе», 18 йөз ахыры, 1862 дә басыла һ.б.). 19–20 йөз башында чит илләргә яки хаҗга барып кайтучылар С. жанрына бик еш мөрәҗәгать итә (Ә.Каргалый, Г.Чокрый, Ш.Мәрҗани, Ф.Кәрими, С.Максуди, Г.Камал һ.б.). Хаҗнамә — С.нең изге урыннарга баруны хикәяләүче бер төре. Бүгенге татар әдәбиятында М.Юныс, Р.Мостафин, Р.Фәйзуллин, М.Мәһдиев, Т.Әйди, Р.Батулла һ.б.ның сәяхәтнамәләре мәгълүм.

*Әд.:* Хәмидуллина А., Хәсәнова Ф. Хәзерге татар әдәбиятында XIX гасырның сәяхәтнамә жанры традицияләре // Milli mədəniət. 2006. № 12; Алеева А.Х. Художественные и стилистические особенности татарских саяхатнамэ XVIII века // Восток в исторических судьбах народов России. Уфа, 2006. Кн. 2; шул ук. Восток и тюркский мир в татарских саяхетнамэ // Уч. зап. Казан. ун-та. Сер. Гуманитарные науки. 2007. Т. 149, кн. 4.

**СӘЯ́ХОВ** Фәнил Лотферахман улы (5.3.1934, БАССРның Дәүләкән р-ны Яскаен а. — 20.11.2002, Уфа ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1985), БР ФАнең мөхбир әгъзасы (1995), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1988). 1958 елда Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, Башкорт ун-тында эшли, гомуми физика (1965–75), гамәли физика һәм геофизика (1984 тән) кафедралары мөдире, физика ф-ты деканы (1989–92), проф. (1987). Хезмәтләре электромагнит кырларының диэлектрик үтешлелек дисперсиясе өлкәсендәге күп фазалы системалар б-н үзара тәэсире физикасына карый. С. поляр тирәлекләр термодинамикасын эшли һәм югары ешлыклы электромагнит кырда үзле углеводород сыеклыгын фильтрлауның матем. моделен гомумиләштерә. Яңа фәнни юнәлеш — югары ешлыклы электромагнит гидродинамикасына нигез сала. Башкортстан Респ-касы Физика җәмгыятен оештыручы һәм аның җитәкчесе (1989–2002). Медальләр б-н бүләкләнә. С. эшләгән ун-т бинасында аның исемендәге аудитория ачылган.

Хезм.: Физические принципы и модели разложения гидратов природного газа. М., 1988; Электротепловые методы воздействия на гидратопарафиновые отложения. М., 2003 (автордаш); Электрофизика нефтегазовых систем. Уфа, 2003 (автордаш).

**СӘЯ́ХОВ** Фәһим Лотферахман улы (20.11.1926, БАССРның Бәләбәй кантоны Чуенчы а. — 20.11.2003, Уфа ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1970), Башкортстан АССРның атказ. фән эшлеклесе (1976). Башкорт пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1948), шунда ук эшли (1989 елга кадәр), 1958–84 тә КПСС тарихы каф. мөдире. Хезмәтләре Башкортстанның социаль-икътисади үсешенә карый. «КПССның Башкортстан оешмасы тарихыннан очерклар» («Очерки истории Башкирской организации КПСС», Уфа, 1973), «Башкортстан АССРның совет историографиясеннән очерклар» («Очерки советской историографии Башкирской АССР», Уфа, 1987) хезмәтләрен төзүчеләрнең берсе.

Хезм.: Осуществление ленинского плана построения социализма в Башкирии (1926–1937). Уфа, 1973.

**СӘЯ́ХОВА** Лена Гали кызы (1.11.1931, БАССРның Дәүләкән пос.), педагог, пед. фән. д-ры (1982), проф. (1986), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1987), РФ югары мәктәбенең атказ. хезмәткәре (2007). 1953 елда Башкорт пед. ин-тын тәмамлаганнан соң, БАССР мәктәпләрендә укыта (1961 гә кадәр). 1964 тән Башкорт ун-тында, рус теле һәм аны укыту методикасы каф. мөдире (1990 нан). Хезмәтләре милли мәктәпләрдә рус теле укыту методикасына карый. Сүзлекләр, уку ярдәмлекләре, милли мәктәпләрдә 5–11 сыйныфлар өчен рус теле дәреслекләре авторы.

Х е з м.: Лексика как система и методика её усвоения. Уфа, 1979; Связный текст как учебная единица на уроках русского языка. Уфа, 1987.

**СБО́ЕВ** Василий Афанасьевич (21.3.1810, Түбән Новгород губ. Чернуха а. — 8.6.1856, Казан), этнограф, Петербург руханилар семинариясен тәмамлый (1833). 1833–40 елларда Казан, 1840 та Сембер руханилар гимназиясендә укытучы. 1841–50 дә Казан ун-тының рус әдәбияты каф. адъюнкт-профессоры. Хезмәтләре Урта Идел буенда яшәүче халыклар — татарлар, чуашлар, мордвалар, марилар, удмуртларның көнкүрешен, мәдәниятен һәм әдәбиятын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Исследования об инородцах Казанской губернии. К., 1856; О быте крестьян в Казанской губернии. К., 1856.

**СВАТКО́** Людмила Георгиевна (5.4.1925, Казан — 24.12.2009, шунда ук), оториноларинголог, мед. фән. д-ры (1970), проф. (1971), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1975). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1948), Казан шәһәренең колак, тамак, борын авырулары клиникасында эшли. 1955 елдан Казан мед. ин-тында, 1968–90 да оториноларингология каф. мөдире. Хезмәтләре үлекле һәм үлексез колак авырулары б-н бәйле саңгыраулыкны өйрәнүгә, онкологиягә, отосклерозны хирургик юл б-н дәвалауга (микрооперацияләр), борын, борын яны куышлыклары, бугаз, йоткылыктагы ялкынсынуларны дәвалауга карый. Уйлап табуга 5 патенты бар. Казан отоларингологлар җәмгыяте идарәсе рәисе (1968–90). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О некоторых принципах профилактики лечения рака гортани // Казан. мед. журн. 1958. № 4; Современные успехи в борьбе с глухотой и тугоухостью. К., 1972; Отосклероз. К., 1974.

*Әд.:* Людмила Георгиевна Сватко (к 80-летию со дня рождения) // Вестн. оториноларингологии. 2005. № 6.

**СВЕРДЛО́ВЕЦ** посёлогы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 80 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 272 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Чишмә авылы пүчинкәсе — Три посёлка исеме б-н дә билгеле. 1920 еллардан Свердловец-1, Свердловец-2, Свердловец-3 буларак та мәгълүм. Беренче булып монда отставной солдатлар яши, соңрак алар дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1120 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән — Яңа Чишмә, 1984 нең 3 июленнән Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 826, 1897 дә — 872, 1908 дә — 916, 1920 дә — 1034, 1926 да — 820, 1949 да — 424, 1958 дә — 685, 1970 тә — 437, 1979 да — 355, 1989 да — 247, 2002 дә — 309 кеше.

**СВЕРДЛО́ВСК ӨЛКӘСЕ́**, РФдә. 1934 елның 17 гыйнварында оештырыла. Мәйданы — 194,3 мең *км*². Үзәге — *Екатеринбург* шәһәре. Халкы — 4320677 кеше (2013). Татарлар саны: 1939 да — 80983, 1959 да — 158222, 1970 тә — 176167, 1979 да — 179341, 1989 да — 187739, 2002 дә — 168143, 2010 да — 143803 кеше. Татарлар, тупланып, Әчет, Әртә, Красноуфимск һәм Түбән Сырга р-ннарында, ш.у. Екатеринбург, Югары Пышма, Каменск-Уральский, Түбән Тагил һ.б. шәһәрләрдә яшиләр. С.ө.нең хәзерге терр-ясенә татарларның урнашуы берничә этапта бара. Беренче этапта (10–13 йөзләр) Идел буе Болгар дәүләтенең фин-угор һәм башкорт кабиләләре б-н үзара сәүдә бәйләнешләре болгарларга өлкәнең көньяк-көнбатыш р-ннарына үтеп керергә мөмкинлек бирә. Икенче этапта (13–15 йөзләр), Алтын Урда чорында, Уралда кыпчак кабиләләре барлыкка килә, бер үк вакытта Көнбатыш Себердән Урта Урал арьягы р-нына Себер татарлары урнаша башлый. Өченче этапта (16 йөз уртасы — 17 йөз) Уралга элеккеге Казан ханлыгы терр-ясеннән татарлар күчеп килә. Алар буш җирләрне үзләштерә һәм башкорт җирләренә кердәшләр хокукында урнаша. Дүртенче этап 19 йөзнең 2 нче яртысында сәнәгатьнең бик көчле үсеше б-н билгеләнә, шунлыктан күп кенә татарлар авыл җирләреннән Урал шәһәрләренә һәм завод посёлокларына күченә. Шәһәр халкының шактый артуы татар төбәгендә милли-мәдәни тормышның җанлануына китерә. 20 йөз башында Урта Уралда Екатеринбург мөселман хуҗалык ком-ты, Красноуфимск, Түбән Тагил, Екатеринбург мөселман хәйрия җәмгыятьләре эшли. 20 йөзнең беренче унъеллыкларында С.ө.ндәге төрки халыкларда элеккеге төрле катламнар арасындагы чикләрне җимерү һәм милли үзаңны тәрбияләү процессы киң үсеш ала, шуның нәтиҗәсе буларак, күп кенә *асаба башкортлар* үзләрен татар дип саный башлый. 1909 елгы мәгълүматларга караганда, Красноуфимск өязе авыллары (Әҗегол, Әртә Шигер, Бакый, Бикән, Бикмәт, Манчаж Тамак, Гайнә) башкорт авыллары булса, 1926 елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча, бу халыклар үзләрен татарлар дип күрсәтә. 1920 елларда — 1930 еллар башында С.ө.нә татарларның *индустрияләштерү* һәм *крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү* чорлары б-н бәйле күченүләренең соңгы этабы уза. Совет властеның беренче елларында татарларның милли тиңдәшлеген саклау сәясәте үткәрелә. 1920 елларда Свердловск татар театры (к. *Урал эшче театры*), Свердловск татар-башкорт пед. техникумы (1919–41), милли мәктәпләр (1953 тә өлкәдә 38 татар мәктәбе — 22 башлангыч, 15 җидееллык, 1 урта мәктәп була) ачыла. Татарлар күпләп яшәгән урыннарда милли колхозлар (1953 тә Манчаж, Сажино, Түбән Сырга р-ннарында 8 татар к-зы исәпләнә) оештырыла. Татар телендә «*Алмашка*», «*Коммунист*», «*Социализм юлы*», «*Яшь коммунар*», «*Ленин байрагы*» г-талары; «Урал мәгарифе» (1930 еллар башы) бюллетене; «Шәпи агай» (1924–27, Свердловск), «Эшче» (1931–37, Надеждинск-Серов ш.), «Очкын» (1932–35, Лысьва ш.), «Ударник» (1935, Манчаж а.), «Алга» (1935, Кушва ш.), «*Бакыр өчен көрәш*», «*Ленин юлы*», «*Мәгариф эшләре*», «*Методик җыентык*» ж-ллары чыга. 1930 еллардагы дингә каршы сәясәт нәтиҗәсендә С.ө.ндә 42 мәчет ябыла. Сугыштан соңгы чорда рәсми рәвештә 1 генә мәчет — Яңа Богалыш авылында эшли. 1980 еллар ахырыннан С.ө. татарларының милли-мәдәни тормышында активлык сизелә. Татар халкын милли һәм мәдәни үстерү мәсьәләләре б-н шөгыльләнүче «Урал» (1988 дән), «Якташ» (1999), «Мирас» (1997) җәмгыятьләре һәм хәйрия фондлары оештырыла, ТР Президентының 1996 ел 25 май Указы б-н С.ө.ндә ТРның даими вәкиллеге, 1997 дә С.ө. татарларының иҗтимагый милли-мәдәни автономиясе оештырыла. Екатеринбургта төрле елларда «Халык авазы» (1991), «Якташ» (1994), «Урал тау» (2000), «Туган ягым» (2000), «Саф чишмә» (2001), «Безнең заман» (2006) татар г-талары чыга. 2013 нең 1 мартында С.ө.нең дәүләт идарәсе органнарында 9 татар җәмәгать оешмалары теркәлә. «Азатлык» татар-башкорт радиосы редакциясе, «Татар-информ» агентлыклары, «Татарстан — Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе (2007) эшли. С.ө. татарларының милли-мәдәни автономиясе каршында телестудия бар, анда татар телендә «Минем илем» тапшыруы әзерләнә, шул ук исемдә газета нәшер ителә (даими чыкмый). 1994 тән Төбәк мөселман Диния нәзарәте, 1999 дан С.ө. мөселманнары Казыят нәзарәте эшли. 80 ләп мәчет һәм мөселман гыйбадәтханәсе бар. «Урал карчыгасы» (2002), «Истина» (2007) г-талары нәшер ителә, эфирга «Ислам сегодня» (2002), «Истина» (2007) телевидение тапшырулары чыга. 2013–14 уку елында С.ө.нең 20 мәктәбендә татар теле фән буларак өйрәнелә. Татар этник мәдәнияте юнәлешендә эшләүче 9 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе (2012), 2014 тә 40 татар үзешчән сәнгать коллективы (10 ысына халык коллективы исеме бирелә) эшли. 1997 дән «Ак барс» спорт-мәдәният үзәге» төбәк иҗтимагый оешмасы эшли; 1998 дә милли көрәш федерациясе оештырыла, көрәшнең бу төре буенча ел саен ярышлар уздырыла. Дәүләт эшлеклесе С.С.*Сәетгалиев*, Сов. Союзы Геройлары С.Г.*Галимҗанов* һәм Н.Х.Нәҗипов, армия генералы М.Ә.*Гәрәев*, атказ. спорт осталары Ә.Б.*Нәҗметдинова*,

Л.Б.*Нәҗметдинова* һ.б.ның тормышы С.ө. б-н бәйле.

*Әд.:* Гурьев Н.А. Национальные меньшинства Урала. М., 1930; Исхаков Д.М. Этнографические группы татар Волго-Уральского региона. К., 1993; Чагин Г.Н. Этнокультурная история Среднего Урала в конце XVII — первой половине XIX в. Пермь, 1995; Научно-информационный вестник истории и этнографии татарского населения Урала. Екатеринбург, 1999. Вып. 1.

*А.Н.Старостин.*

**СВЕРДЛО́ВСК ТАТА́Р ТЕА́ТРЫ**, к. *Урал эшче театры.*

**СВЕРИ́ГИН** Рифат Хәсән улы (1.8.1932, Саба р-ны, Байлар Сабасы а.), әдәбият галиме, филол. фән. канд. (1971). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1955), ТАССР районнарында урта мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбияты укыта. 1961 елдан СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1972–2011 дә Казан пед. ун-тында (2000 нән профессор). Хезмәтләре 20 йөз прозаикларының стиль һәм сәнгать осталыгына, татар прозасының шигърияттенә карый.

Хезм.: Фатих Хөсни. К., 1968; Яңа герой һәм яңа алымнар. К., 1985.

*Әд.:* Рифат Свериггинга — 70 яшь // Казан утлары. 2002. № 8.

**«СВЕРХРА́ННЯЯ»**, слива сорты. Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында 1975 тә Л.А.*Севастьянова*, Г.Е.*Осипов* тарафыннан чыгарыла. Салкынга һәм авыруларга чыдамлылыгы уртача, корылыкка һәм эссегә чыдам, җимеш бирүчәнлеге югары. Агачы зур түгел, уртача куелыктагы шарсыман ябалдашлы. Кайрысы кәүсәдә һәм төп ботакларында кытыршы, көрән, ачык көрән төстә. Үрентеләре нечкә, кызгылт-көрән төстә, төксез. Ясмыкчыклары күп, вак яисә уртача, ачык көрән, ачык соры төстә. Яфраклары вак, сирәгрәк уртача зурлыкта, кире йомыркасыман, очлы, ачык яшел, тонык төстә. Яфрагы чыгынты, аз төкле. Бөредән ике чәчәк үсә. Таҗлары озынча, кире йомыркасыман, вак, ак. Чәчәк атуы майның 2 нче декадасында башлана. Җимешләре вак (уртача авырлыгы — 12,3 *г*), кызыл-шәмәхә төстә, балавызлы кунлыгы уртача дәрәҗәдә. Җимешенең тиресе юка, җимеш йомшагы яшькелт-сары, әчкелтем-баллы, нечкә җепселле. Июльнең өченче, августның беренче декадасында өлгерә башлый. Бер агачтан уртача уңышы 5,4 *кг*. Иң яхшы серкәләндерүче сортлары — «Скороспелка красная», «*Тәмте ренклоды*». Нигездә, күмәк һәм йорт яны бакчаларында үстерелә. Татарстанда 2001 дән районлаштырыла.

*Әд.:* Фруктовый сад Татарстана. К., 2005.

*Г.Е.Осипов.*

**СВЕРЧКО́В** Дмитрий Николаевич (4.5.1874 — ?) җәмәгать эшлеклесе, 4 нче Дәүләт Думасы депутаты (1912–17). Дворяннар катлавыннан. Константин артиллерия уч-щесен тәмамлый. Казан губернасының Тәтеш өязендә 1095 дис. җир хуҗасы. 1898 елда артиллерия поручигы дәрәҗәсендә, хәрби хезмәттән отставкага чыккач, Казанда һәм Тәтеш өязенең Красная Поляна авылында яши. Төрле земство һәм җәмәгать вазифаларын башкара: Тәтеш өязенең 2 нче участок земство башлыгы, Крәстиян җир банкы Казан бүлегенең тәгаен әгъзасы, Казан земство җыеынының губерна гласные, Тәтеш өязе буенча шәрәфле җәмәгать судьясы. Думада үзәк төркеменә керә; җир, хәрби-диңгез, мәхкәмә реформалары, матбугат комиссияләре әгъзасы. 1917 дә Тәтеш өязе дворяннары җитәкчесе итеп сайлана. Аннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Казанское дворянство. 1785–1917 гг.: Генеал. словарь. К., 2001; Усманова Д.М. Депутаты от Казанской губернии в Государственной думе России. 1906–1917. К., 2006.

**СВЕТЛАКО́В** Николай Владимирович (4.12.1931, Мари АССРның Куженер р-ны Шенжа а.), химик-технолог, химия фән. д-ры (1972), проф. (1973), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1997). 1954 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, лаклар һәм буяулар технологиясе каф. мөдире (1972–96), технол. ф-ты деканы (1973–93). Хезмәтләре органик химиягә карый. С. чикле углеводородларны, галогеналкилларны һәм аларның чыгарылмаларын нитроксиллау реакцияләрен, азот к-тасы эфирларының яңа реакцияләрен эшли. Уйлап табуга 40 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Реакция нитролиза органических галогенидов // Журн. орган. химии. 1971. Т. 7, вып. 6 (автордаш); Реакция алканов со смесью азотной кислоты и уксусного ангидрида // Журн. орган. химии. 1998. Т. 34, вып. 8 (автордаш).

**СВЕТЛОГО́РСКИЙ** посёлогы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасы (Олы Сөлчәнең уң кушылдыгы) бассейнында урнашкан. 2010 елда 70 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек; урман сәнәгате хуҗалыгы. Тулы булмаган урта мәктәп. Торак пункт булырак 1963 тә теркәлә. Оештырылган көненнән Октябрь р-нында. 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1989 да — 146 кеше, 2002 дә — 111 кеше.

**СВЕ́ТЛОЕ О́ЗЕРО**, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 29 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сумка елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 4 кеше (руслар) яши. 1919 да нигез салына. Беренче исеме — Светлозёрка. Оештырылган көненнән Казан губернасының Казан өязе Кукмара волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1920 дә — 61, 1926 да — 62, 1938 дә — 65, 1949 да — 150, 1958 дә — 68, 1970 тә — 19, 1979 да — 10, 1989 да — 11, 2002 дә — 3 кеше.

**СВЕ́ТЛЫЙ РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1965 елның 12 гыйнварында оеша. Мәйданы — 1005,6 $км^2$. Үзәге — шәһәр тибындагы Светлый посёлогы (Оренбургтан 522 *км* көнчыгыштарак). Халкы — 12884 кеше (2013). Татарлар саны: 1989 да — 708, 2002 дә — 541, 2010 да — 364 кеше. Татарларның хәзерге С.р. терр-ясенә күченүләре 1954 елда чирәм җирләрне үзләштерү б-н бәйле.

**СВЕ́ШНИКОВ** Александр Никифорович (1825, Казан — 1889, шунда ук), Казан сәүдәгәре. Башта Оренбург губернасының Богырыслан шәһәрендә сәүдә б-н шөгыльләнә, аннан соң Казанда сәүдәгәр А.С.Меркулов б-н бергә үзләренең пр-тиесен оештыра. 1851 елда Казанның Адмиралтейство бистәсендә чуен кою з-ды хуҗасы (хәзер «Урак һәм Чүкеч» з-ды), анда, башлыча, кораблар ремонтлана. Йортлар хуҗасы; шәһәр ихтыяҗлары өчен төрле эшләр башкара (мәс., 1873 тә шәһәр халкына — азык-төлек, полиция һәм янгын сүндерү командаларына кием-салым һ.б. кирәкле әйберләр кайтарта). 1857–60 та Казан шәһәр магистраты ратманы, 1871–77 дә Казан шәһәр Думасы гласные. Янгыннан соң шәһәр театрын яңадан төзү (1874), Казанда реаль уч-ще ачу (1875) комиссияләре эшчәнлегендә катнаша. 1871–74 тә Казан җәмәгать банкы директоры иптәше (урынбасары), 1875–79 да Казан җәмәгать банкының исәпкә алу ком-ты әгъзасы, 1873 тән Үзара кредитлашу җәмгыятенең ревизия комиссиясе әгъзасы. 1881 дә Казан биржа ком-ты старейшинасына кандидат итеп сайлана. 1882 дән Казан икътисад җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы. Гостиный двор попечителе. Анна тасмасында — көмеш, Станислав тасмасында алтын медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Золотые страницы купечества, промышленников и предпринимателей Татарстана. К., 2001. Т. 2.

**СВИНОГО́РЬЕ** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 46 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кама елгасы буенда. 2010 елда 53 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Клуб. 1668 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Свиные Горы, Рождественский исемнәре б-н билгеле. Башта Раифа Богородица монастырена карый, 1763 тә халкы — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Христо-Рождество чиркәве, земство мәктәбе, халык китапханәсе (1901 дә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4116,7 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Казиле волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 1606, 1887 дә — 1696, 1905 тә — 1834, 1920 дә — 1494, 1926 да — 1544, 1938 дә — 1000, 1949 да — 916, 1958 дә — 685, 1970 тә — 412, 1979 да — 215, 1989 да — 118, 2002 дә — 67 кеше. С. тирәсендә *Свиногорье комплексы* урнашкан.

**СВИНОГО́РЬЕ КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Алабуга р-ны Свиногорье а. янында урнашкан. С.к. истәлекләрен тикшерү 1880 еллардан башлап алып барыла: 1887 дә — А.А.Спицын, 1894 тә — Ф.Д.Нефёдов, 1925 тә — А.В.Збруева, 1943 тә — В.П.Мизинова, 1959 да А.Х.Халиков һ.б. тарафыннан өйрә-

нелә. Комплекс таш, бронза һәм тимер гасырлар истәлекләрен, ш.у. Кама һәм Вятка елгалары кушылган урында урнашкан Ананьино культурасына караган шәһәрлекне (1884 тә Н.Савельев тарафыннан ачыла) үз эченә ала. Шәһәрлек чокырлар арасындагы борынны били, аның озынлыгы 142 *м* һәм киңлеге 33 *м* га җитә, суга караган яктан туфрак уры һәм чокыр б-н киртәләп алынган. С.к.на караган терр-ядә күпсанлы бронза, тимер һәм сөяк эшләнмәләр (пычаклар, беләр, уклар, бил каешы бизәмәләре һ.б.), керамика кисәкләре һ.б. табыла.

*Әд.:* Мизинова В.П. Археологические разведки в районе города Елабуги Татарской АССР // Краткие сообщ. Ин-та истории материальной культуры АН СССР. 1946. Вып. 13; Археологическая карта Татарской АССР. Предкамье. М., 1981; Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987.

*Е.П.Казаков.*

**СВИ́РСКИЙ** Иосиф Вениаминович (21.2.1917, Петроград — 16.5.1993, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1964). 1938 елда Белорус ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук, математика кафедрасында эшли. 1941 дән Куйбышев шәһәрендә: пед. ин-т укытучысы (1941–43), авиация (1944–45) һәм индустриаль (1945–46) ин-тлар хезмәткәре. 1946–86 да СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында эшли. Хезмәтләре сыгылмалылык һәм сыгылымлылык теориясендәге мәсьәләләрен чишүдә якынчалык алымнарын эшләүгә һәм куллануга, чишү нәтиҗәләренең төгәллеген бәяләүгә карый. С. сыгылмалылык һәм сыгылымлылык теориясе мәсьәләләрен чишү өчен гомуми характердагы һәм исәпләү нәтиҗәләре интуитив сайлап алынган функцияләрнең хаталарына (тирбәнү ешлыкларын һәм критик көчләрне, бөгелешләрне, аларның моментларын һ.б. билгеләгәндә) аз бәйләнгән вариатив формулалар тәкъдим итә. Сыгылымлылык исәпләүнең зур классы өчен эзлекле якынчалыклар алымын камилләштерә. Сәнәгатьтә кулланыла торган оптик конструкцияләрне исәпләү эшендә катнаша.

Хезм.: Методы типа Бубнова-Галёркина и последовательных приближений. М., 1968; Метод прогонки для расчёта конструкций, состоящих из оболочек // Теория пластин и оболочек. М., 1971; Функции усилий для плоских рам // Статика сооружений. Киев, 1978.

**«СВИЯ́ГА»**, радиоэлектроника приборлары пр-тиесе. 1942 елның мартында СССР Авиация сәнәгате халык комис-тының 1941 нең августында Ленинградтан эвакуацияләнгән 379 нчы тәҗрибә з-ды (1938 дә оештырыла) җирлегендә п/я 466 оешмасы буларак төзелә. 1943 тән — СССР Суднолар төзү сәнәгате халык комис-ты, соңрак — министрлыгы карамагында. 1967–77 дә һәм 2002 дән Казан электр техникасы з-ды (КЭТЗ). 1977–2002 дә Татарстан «С.» ЖБ. 2004 тә КЭТЗ акционерлаша, 2005 тә — Уртача һәм кече тоннажлы корабльләр төзү дәүләт концерны, 2009 да «Россия технологияләре» дәүләт корпорациясенең «Радиоэлектроника технологияләре» концерны составына керә.

Бөек Ватан сугышы елларында пр-тие ликёр-аракы з-ды мәйданнарында урнаша, Кораллы көчләрне артиллерия һәм диңгез кораллары автоматикасы системалары б-н тәэмин итә. Беренче продукциясе 1941 дә «ПУАЗО-3» артиллерия-зенит уты б-н идарә итү приборлары була. 1943 тә кыска вакыт эчендә «ПУТС» торпедалар җибәрү б-н идарә итү, «СПРУТ» су асты көймәләрен автоматик стабилизацияләү приборлары, «КЛН» корабль төзәү линейкалары җитештерү оештырыла. 1944 тә махсус техниканың яңа төрләрен чыгару үзләштерелә, сугыштан соңгы чорда пр-тие илдә фарватерлар өчен маяклар һәм төрле сигнал аппаратлары эшләүдә әйдәп баручыга әверелә; гидроакустик тирәнлек үлчәгечләр, ш.и. 1951–53 тә визуаль индикатор һәм үзъязгыч б-н җиһазландырылган, 2000 *м* га кадәр диапазонлы «НЭЛ-5» навигация эхолотын проектлый һәм җитештерә, иң кенчел радиолокация станцияләрен эшләүгә керешә. 1954–65 тә СССР Оборона министрлыгы өчен радиолокацион тану-ачыклау эшләнмәләренең 20 дән артык яңа төрләрен («Лоза», «Дозор», «Тюльпан», «Нихром», «ВИКО», «УВИКО», «КПИ», «Касатка» һ.б.) серияләп җитештерү үзләштерелә. 1965 тә бөтенләй яңа төр техника — канатлы ракеталарны төзәү системасының радиолокацион хәлне чагылдыру приборларын һәм башка компонентларын («NPO», «Дрофа-МТ», «Метель-МТ») эшләүне үзләштерү һәм серияләп җитештерү башлана. 1970 еллар башында — 1980 елларда халык куллану товарлары — яхшыртылган сыйфатлы «Рондо» сериясеннән моно- һәм стереоэлектрофоннар, «Сонет» стереосистемалары эшләп чыгарыла. Җитештерелүче продукциянең үрнәкләре һәм күләме арту интенсив рәвештә җитештерү куәтләрен төзүгә (1940 еллар ахырыннан), Махсус КБ оештыруга, специальләшкән сынау участоклары булдыруга, технологияләрне камилләштерүгә этәргеч бирә. 1971–80 дә реконструкция һәм модернизация барышында берничә корпус төзелә һәм яңа цехлар оештырыла, заманча станоклы металл эшкәртү (ш.и. санлы программалы идарәле) һәм пресслау җиһазлары, роботлар һәм дозаторлар куелган кою машиналары урнаштырыла. «С.» берләшмәсе диңгездә кулланылучы дәүләт тану-ачыклау системаларын җитештерүче төп пр-тиегә әверелә. Эшләүчеләр саны 7 мең кешегә җитә (1990). 1990–2000 елларда, оборона заказлары булмаган шартларда, гражданлык куллануы 30 дан артык төрдә электр приборлары конструкцияләнә һәм эшләп чыгарыла. 2003 тән яңадан махсус техника җитештерү күләмнәре арта башлый. Өлешчә реконструкция уздырыла, табаклы металлны плазма б-н кисү җайланмасы, фрезерлы эшкәртү үзәге, чит илләрдә эшләнгән җыю-монтажлау җиһазлары куллануга кертелә; ГОСТ 15.002–2003, ГОСТ ИСО 9001–2001 стандартларына туры килгән сыйфат менеджменты системасы эшләнә һәм кабул ителә.

Заводның төп производстволары: металл эшкәртү, штамплау-каркаслау, чорнау-урау, кою, гальваника һәм лаклау-буяу, пластмасса эшкәртү, коелган платалар ясау, җыю-монтажлау, агач эшкәртү, инструментлар производствосы; ярдәмче производстволар — транспорт һәм энергетика цехлары. Бүлекләр: конструкторлык, технол., стандартлаштыру һ.б.; лабораторияләр: типлы сынаулар, керү контроле. Эшләүчеләр саны — 1000 нән артык кеше (2013).

Пр-тие үз продукциясен чит илләргә чыгара (1963 тән Индонезия, Ливан, Ливия, Греция, Польша, Германия, Чехословакия, Венгрия, Румыния, Югославия, Кубага җибәрелә; хәзерге вакытта продукция Кытай, Вьетнам, Һиндстан, Алжирга озатыла).

Бишьеллык планны (1966–70) уңышлы үтәгән һәм яңа техника җитештерүне оештырган өчен завод Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә (1971). Күп кенә эшчеләре дәүләт бүләкләренә лаек була: 3 кешегә СССР Дәүләт бүләге, 1 кешегә Ленин бүләге, 5 кешегә ТРның атказ. машина төзүчесе исеме бирелә; 6 кеше — Ленин ордены, 5 кеше — Октябрь Революциясе, 45 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 2 кеше — Халыклар дуслыгы, 67 кеше — «Почёт билгесе», 4 кеше — 2 нче дәрәҗә Хезмәт Даны, 31 кеше — 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны орденнары, 940 тан артык кеше медальләр б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре: В.Т.Быстров (1941–45), В.В.Коцура (1946–47), С.Н.Козырев (1948–52), Г.П.Тихонов (1953–59), Э.И.Сакс (1960–62), В.П.*Ханеев* (1963–89), Г.Г.Агаджанов (1989–96), А.Г.Гафаров (1996–2002), В.С.Гинсбург (2002 дән).

**СВИЯ́ЖНЫЙ** посёлогы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 6 *км* төньяк-көнбатыштарак, Казан–Ульянов автомобиль юлы буенда. 2010 елда 558 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 79%) яши. Ремонт-техника пр-тиесе. Башлангыч мәктәп. Мәчет. 1963 тә нигез салына. Оештырылган көненнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1970 тә — 109, 1979 да — 192, 1989 да — 490, 2002 дә — 566 кеше.

**СВИЯ́ЖСК**, к. *Зөя*, Яшел Үзән р-ны.

**СВОБО́ДНЫЙ ТРУД** посёлогы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 51 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мордвасу елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 5 кеше (руслар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Зөя кантоны Тәмте волостенда. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Кама Тамагы, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1926 да — 10, 1938 дә — 152, 1949 да — 70, 1958 дә — 98, 1970 тә — 85, 1979 да — 64, 1989 да — 25, 2002 дә — 9 кеше.

**СВЯ́ТКИНА** Клавдия Андреевна (10.2.1912, Казан — 8.10.1990, шунда ук), педиатр, мед. фән. д-ры (1955), проф. (1959), ТАССРның һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1964, 1970). Проф. Е.М.Лепский шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1933), Морд-

ва АССРның Ромодан хастаханәсендә эшли. 1937 елдан Казан ГИДУВында. 1941–44 тә Казан госпитальләрендә хәрби табиб. 1944–85 тә Казан мед. ин-тында, факультет педиатриясе каф. мөдире (1955–80), бер үк вакытта, 1955–60 та, педиатрия ф-ты деканы. Хезмәтләре рахит һәм рахитсыман авырулар патогенезына, бу авыруларны кисәтү һәм дәвалау ысулларына, сөяк эченә кан салуга карый. ТАССР Балалар табибләре җәмгыяте рәисе (1959–80). «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К изучению баланса никотиновой кислоты у здоровых детей. К., 1951; Рахит, его профилактика и лечение. К., 1963.

*Әд.:* Профессор Клавдия Андреевна Святкина // Казан. мед. журн. 1982. № 2.

**СВЯТОСЛА́В I** (? — 972 яки 973), Киев Русенең бөек кенәзе (945–73 тирәсе). Кенәз Игорь улы. Балигъ булганчы һәм хәрби яулар вакытында дәүләт б-н әнисе, княгиня Ольга идарә итә (969 елга кадәр). 946–66 да С. I хәзәрләргә ясак түләгән вятичлар җирләрен үзенә буйсындыра. Хәзәр каганлыгына яулар оештыра, Саркел шәһәрен (965), каганлыкның башкаласы Итил шәһәрен (969) җимерә. Төньяк Кавказга яу б-н бара, Сәмәндәр кальгасын яулап ала, яс һәм касог (кашак) кабиләләрен җиңә, Таматарха кенәзлегенә нигез сала. С. I Идел буе Болгар дәүләтенә яу оештырган (965) дип фаразлана, ләкин бу фикер расланмый. 967–68 дә Византия б-н килешү төзеп, Дунай елгасы буендагы Болгар дәүләтенә (к. *Беренче Болгар патшалыгы*) бәреп керә, аны яулый, Дунай буендагы Переяславец шәһәрен башкала итә. Византия, кенәзне Балканнан кысрыклап чыгару максаты б-н, Киевка бәҗәнәкләр яуларын оештыра. С. I, яуларны куып, Болгар патшалыгына кире кайта һәм Византия б-н сугыш башлый (971 тирәсе). Византия императоры Цимисхий гаскәрләре тарафыннан берничә тапкыр җиңелә, Дунай буендагы Доростол шәһәрендә камап алына. 3 ай камалышта булганнан соң, Цимисхий б-н солых килешүе төзи һәм Болгар патшалыгыннан чыгып китә. Киевка кайтып барганда бәҗәнәкләр тарафыннан үтерелә.

Чыг.: Повесть временных лет. СПб., 1996; Л е в Д и а к о н. История. М., 1988.

*Әд.:* Г р е к о в Б.Д. Киевская Русь. М., 1953; К а л и н и н а Т.М. Сведения Ибн Хаукаля о походах Руси времён Святослава // Древнейшие государства на территории СССР. М., 1976; Р ы б а к о в Б.А. Киевская Русь и русские княжества XII–XIII вв. М., 1982; С а х а р о в А.Н. Дипломатия Святослава. М., 1982.

*И.Л.Измайлов.*

**СЕБЕ́Р**, к. *Кашлык*.

**СЕБЕ́Р ЗАСТА́ВАСЫ**, Казаннан чыкканда Арча кыры юлындагы *Варвара чиркәве* янәшәсендә, ермак аша салынган, хәрби каравыл сагындагы таш күпер. 1806 елда арх. Я.М.*Шелковников* тарафыннан рус классицизмы стилендә төзелә. Шәһәрдән Себергә илтүче Арча юлы өстендәге бер торыклы аркалы күперне хәтерләтә. Биредән Себер тракты — хөкем ителгәннәрнең сөрген һәм каторга юлы башланган. Парлы колонналар һәм шома фронтонлы, ике кыеклы биек түбәле корылма ионик ордерлы ике сигез кырлы колонна б-н капланган. Портиклар күпернең ике ягына үтәли уемлы, турыпочмаклы пьедесталга урнаштырылган. Күпернең терәк диварлары һәм пьедесталлары пилястралар һәм кытыршы ташлар б-н ныгытылган. Портикларның ян-якларындагы колонналар арасында һәм парапетларда зур пирамидаль тумбалар куелган. Портикларны 1841 дә алалар. 1892 дә, тузу сәбәпле, күперне сүтәләр, ермакны күмәләр.

*Әд.:* Т у р н е р е л л и Э.П. Собрание видов города Казани, рисованные с натуры. СПб., 1839; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

*Х.Г.Надыйрова.*

**СЕБЕ́Р ТАТАРЛАРЫ́** (үзатама сибиртар), татар халкының этнотерр. төркеме. Башлыча, Новосибирск, Омск, Томск һәм Төмән өлкәләрендә яшиләр. 1897 елгы халык санын алу буенча 46 мең кеше, 1926 елда 7 меңнән артык, 2002 дә 9611 кеше исәпләнә (башка вакытта халык санын алганда С.т. аерым төркем буларак каралмый). Сөйләмнәре татар теленең көнчыгыш диалектына карый. Язулары 1939 дан рус алфавитына нигезләнгән. Нигездә, ислам динен тоталар (сөнниләр). С.т. арасында мөселман, тубылык (Тубыл шәһәренә нисбәтле), төмәнлек (Төмән), бараба (бараба татарлары) һ.б. этнонимнар була. С.т. составында 3 этнографик төркемне аералар: тубыл-иртеш (курдак-саргат, тара, тубыл, төмән һәм ясколбин татарлары), бараба (бараба — тураж, лүбәй — тунус һәм теренин-чой татарлары), Том буе (колмак, чат һәм эуштин). С.т.ның этномәдәни үзенчәлекләре барлыкка килүдә төркиләр, фин-угор, самодий һәм өлешчә монгол халыклары хәлиткеч роль уйный. С.т. *Алтын Урда*, ул таркалгач барлыкка килгән *Себер ханлыгы* дәверләрендә формалаша. Соңрак аларга Бохара төбәгеннән килгән төркиләр (*Бохари төркиләр*) һәм 16 йөздә — 20 йөз башында Себергә күченгән Идел буе-Урал алды татарлары йогынтысы зур була. 17–19 йөзләрдә, Себер җирләре руслар тарафыннан үзләштерелү б-н бәйле рәвештә, С.т.ның барлык төркемнәренең таралышы җитди үзгәрешләр кичерә (торак пунктларның зураюы, яшәү терр-ясе чикләре үзгәрү һ.б.). 2007 дән Тубыл шәһәрендә халыкара «Искер-җыен» фестивале уздырыла, аның кысаларында конференцияләр, концертлар һ.б. була.



Енисей һәм Томск губерналарындагы Себер татар хатын-кызлары. Кошарев оригиналыннан К.Ф.Гунн рәсеме буенча литография. Кәгазь. Төсле литография. 1862.

С.т.ның төп шөгыльләре — игенчелек (бодай, арыш, солы, тары игү) һәм терлекчелек. Бараба татарларында күлдән балык тоту, тубыл-иртеш төньяк төркемендә елгадан балык тоту һәм аучылык зур роль уйный. С.т. электән үк күнчелек, савыт-саба, күчеп йөрүнең традицион әйберләрен (арба, чана, көймә һ.б.) ясау, мунчаладан бау ишү (төмән һәм ясколбин татарлары), ятьмәләр, тал чыбыкларыннан әрҗәләр үрү һ.б. эшләр б-н шөгыльләнәләр. 19 йөздә — 20 йөз башында С.т.ның күбесе сәүдә, читкә китеп эшләү (казна урманнарында, такта яру з-дларында һ.б.да) һәм йөк ташу (башлыча, сәүдәгәрләр йөген ташу) б-н мәшгуль булганнар.

Себер ханлыгы чорында терр. күршеләр җәмәгате (общинасы) хөкем сөрә (бараба һәм ясколбин татарларында ыруглык-кабилә мөнәсәбәтләре калдыклары сакланган). 19 йөзнең 1 нче яртысына кадәр Көнбатыш Себердә яшәүче татар халкының төп өлешен *ясаклылар* — гади община кешеләре тәшкил итә. С.т. арасында йомышлы татарлар — казаклар, бәйле татарлар, салымны морҗа башыннан түләүче татарлар төркемнәре, ш.у. морзалар, сәүдәгәрләр, руханилар катлаулары була. Россия законнары б-н барлык С.т. да диярлек утрак әҗнәбиләр төркеменә кертеләләр (1822 дән).

18 йөз башына кадәр С.т.нда землянкалар һәм ярымземлянкалар киң тарала. Шулай ук җир өстендә төзелгән буралы корылмалар (түбән түшәмле, тәбәнәк ишекле), балчыктан, кәстән, кирпечтән салынган йортлар да очрый. Соңрак С.т. русларныкы кебек йортлар сала башлыйлар (буралы йортлар, сәүдәгәрләр һәм мул тормышлы шәһәр халкы таш корылмалар төзи). С.т.ның һәр төркеменең йорт интерьерында үзенчәлекләр була, ләкин торакларның күбесендә үзәк урынны аларның келәмнәр, киезләр ябылган сәкеләр били, кырыйларына сандыклар һәм урын-җир әйберләре куела. Өйләрдә кыска аяклы өстәлләр, савыт-саба өчен киштәләр (мул тормышлыларда — шкафлар, урындыклар һ.б. җиһазлар) файдаланыла. С.т.ның авыллары (ауллар, йортлар, Томск татарларында — улуслар, аймаклар), башлыча, елгалар һәм күлләр буйларында урнашкан. Юллар төзелү нәтиҗәсендә, олы юл буенда авыллар барлыкка килә. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында күпчелек авыллар өчен туры урамнар хас. Йортлар урамның ике ягында, сирәгрәк (башлыча, яр буендагы авылларда) бер ягында урнаштырыла. Кагыйдә буларак, агачтан, кайбер авылларда (мәс., Тубыл губернасы Төмән өязе Эмбай авылында) кирпечтән салынган мәчетләр аеруча мөһим корылмалар булып торалар.

18 йөздә — 20 йөз башында С.т.нда традицион форма булып кече гаилә (уртача 5–6 кешелек гаилә) исәпләнә. Идарә итү хокукына

тулысынча гаилә башлыгы (гадәттә, өлкән ир-ат — бабай, әти, абый) ия була, ул гаилә тормышының эчке тәртибен билгели. Хатын-кыз иреген чикләгән тәртипләр (мәс., кыз балаларны аларның ризалыгыннан башка кияүгә бирү йоласы, урамда битне ачып йөрүне тыю һ.б.) катгый саклана. Хәзерге вакытта гаиләләр ике (сирәгрәк өч) буыннан һәм 3–5 кешедән торалар. «Гаилә башлыгы» төшенчәсе саклана, шулай да күп кенә гаиләләрдә эшләр киңәшләшеп хәл ителә.



Себер татар хатын-кызының бәйрәм костюмы.
Әлмәт шәһәренең туган якны өйрәнү музее.

Элек традицион ирләр эчке киеме күлмәк-ыштаннан гыйбарәт була. Өске киемнәрдән (ш.и. хатын-кызларныкы да) бишмәтләр — җиңле озын төймәсез кафтаннар, җиңсез яки кыска җиңле камзуллар, тәнгә сыланып торган җиңсез кафтаннар, толыплар һәм туннар, өйдә тукылган тукымадан яки Урта Азиядән кайтарылган тукымалардан тегелгән халатлар (чапаннар) киелә. 19 йөздә — 20 йөз башында С.т. кулланылышында рус дохалары (туннары), кыска туннар, чикмәннәр, ирләр күлмәкләре — кыек якалы ирләр күлмәкләре, чалбарлар, хатын-кыз күлмәкләре киң тарала. Ирләр түбәтәйләр (кәпәч, түбәтәй, аракчин), киез башлыклар (бүрек), төрле төрдәге кышкы сырылган башлыклар (ш.и. көрәксыман чыгынтылы) кигәннәр. Хатын-кыз баш киемнәре арасында — маңгай бәйләвече (сараоч, сарауц) аеруча киң тарала, ул катыргы өслектә тукыма б-н тегелгән һәм укалы тасма, сәйлән б-н чигелгән була. Бәйләнгән яки ефәк һәм бәрхет тукымалардан тегелгән зур үлчәмле (сәйлән һәм йон җеп б-н чигелгән һ.б.), бәрхет тукымадан катыргы кырпулы, үлчәм буенча кечерәк калфаклар бәйрәмдә кия торган баш киеме булып саналган. Хатын-кызлар шулай ук цилиндр формасындагы башлыклар кигәннәр, аның өстеннән яулык һәм шәл бәйләгәннәр. Хатын-кыз киемнәрен алтын, көмеш, сәйлән, тәңкәдән гыйбарәт бизәнү әйберләре (беләзекләр , балдаклар, йөзекләр, алкалар, муенсалар һ.б.) тулыландырган. С.т.нда йомшак күннән тегелгән каюлы *читекләр*, күн башмаклар, йон итекләр (пима), кыска чирки, ауга йөри торган итекләр һ.б. аяк киемнәре киң таралган.

С.т.нда традицион азык-төлекләреннән ит-сөт һәм камыр ризыклары өстенлек алган. Төп ризыклары ат казылыгы (казы), пилмән, төрле ашлар (шурпа, тары үрә, күчә үрә, көреч үрә, токмачлы — онаш, салма, умач һ.б.), боткалар, талкан (төелгән арпа һәм солы бөртекләреннән, суда яки сөттә әзерләнә), пәтер, төрле эчлекле пәрәмәчләр, бәлешләр, сумсалар), хәлвә (алюва); чәй, *әйрән, кымыз* һ.б. эчемлекләрдән гыйбарәт.

Элек С.т.нда төрле уеннар актив ял итү төрләре булган: кузна (бура уенына охшаш), жуга (ир-атлар үзаман тирәли басалар һәм аның башлыгын төшерергә тиеш булалар; үзәктә уйнаучы каршы торырга һәм үз көчен, җитезлеген күрсәтергә тиеш) һ.б. Бараба һәм Томск татарлары яши торган кайбер авылларда 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башына кадәр башка тел культларының эзләре саклана — шаманнар (камнар) авыруларны дәвалыйлар һәм корбан чалган вакытта фал ачалар (күрәзәлек итәләр). Хәзерге вакытта С.т. арасында мөселман бәйрәмнәре һәм (*Ураза бәйрәме, Корбан бәйрәме*) ислам дине кабул ителгәнче барлыкка килгән бәйрәмнәр (*Сабан туе* һ.б.) яшәүләрен дәвам итә.

С.т. бай фольклор мираска ия. Ул риваятьләр һәм легендаларны, фантастик һәм көнкүреш әкиятләрен (йомаклар), мәкальләр һәм әйтемнәрне (лагаплар), табышмакларны, лирик һәм йола җырларын (йырлар), эпик характердагы әсәрләр — *дастаннар* һәм *бәетләрне*, такмакларны, дини характердагы кыска җырларны — *мөнәҗәтләрне*, мәсәлләрне үз эченә ала.

Совет чорында, *руслаштыру сәясәте*, шәһәрләшү темплары көчәю һ.б. б-н бәйле рәвештә, С.т.ның традицион мәдәнияте һәм көнкүреше беркадәр үзгәрешләргә дучар була: татар мәктәпләре үзгәртеп корыла, татар газетлары чыгудан туктый. 1980 еллар ахыры — 1990 еллар башында С.т. арасында милли үзаң үсеше, халыкның килеп чыгышы, тарихы, мәдәнияте, тел үсеше һ.б. б-н кызыксыну күзәтелә. Көнбатыш Себер өлкәләре терр-ясендә иҗтимагый оешмалар: «Азат Себер» татар иҗтимагый үзәге (Новосибирск өлкәсе), «Туганлык» мәдәни-агарту оешмасы (Томск өлк.), С.т. Ассоциациясе (Төмән өлкәсе) һ.б. оештырыла, аларның максаты — С.т. милли үсешенә тәэсир итү, башка төркемдәге татарлар б-н икътисади һәм мәдәни бәйланышларны, РФ халыклары арасында дуслыкны һәм үзара аңлашуны ныгыту.

*Әд.:* Бояршинова З.Я. Население Западной Сибири до начала русской колонизации. Томск, 1960; Томилов Н.А. Современные этнические процессы среди сибирских татар. Томск, 1978; шул ук. Этническая история тюркоязычного населения Западно-Сибирской равнины в конце XVI — начале XX вв. Новосиб., 1992; Валеев Ф.Т. Западно-сибирские татары во второй половине XIX — начале XX вв.: Ист.-этногр. очерки. К., 1980; шул ук. Сибирские татары. К., 1993; Исхаков Д.М. Сибирские татары // Татары. М., 2001.

*Р.Р.Батыршин.*

**«СЕБЕ́Р ТРА́КТЫ ТАРИХЫ́» ҺӘМ МУСА́ ҖӘЛИ́Л МУЗЕЕ́**, Балтач р-ны Карадуган авылында, 1993 елда оеша, 1995 тә ачыла. 1995–2006 да ТР Милли музее ф-лы; 2007 дән муниципаль музей. Нигез салучысы һәм директоры (2011 гә кадәр) Б.Ш.Зыятдинов. 2 нче гильдия сәүдәгәр М.М.Мөлековның элеккеге ике катлы кунакханә бинасында урнашкан (1911; псевдорус юнәлешенең эклектика стилендәге архит-ра истәлеге). Экспозиция мәйданы — 245 *м²*, коллекцияләре 5 меңнән артык саклау берәмлеге исәпләнә. Бинаның беренче катында Муса Җәлил музее урнашкан (мәктәп музее буларак 1976 елдан эшләп килә, 1981 дән хәзерге бинада). Экспозициянең төп бүлекләре: «Бөек Ватан сугышында катнашучы якташларыбыз», «Себер тракты тарихы», «Карадуган авылы тарихы», «Почта элемтәсе тарихы». Экспозициянең авторлары — ТР Дәүләт музее (хәзер ТР Милли музее) фәнни хезмәткәре Д.Б.Баһаветдинова, рәссам Б.М.Салосин. Сугышчан дан залында «Үлем үзәне»ннән Бөек Ватан сугышы чоры табылдыклары (каскалар, снаряд кыйпылчыклары, патрон гильзалары, пулемёт дисклары һ.б.), шушы төбәктә туып үскән, Мәскәүдә Кызыл мәйданда ике тапкыр Җиңү парадында катнашкан Мәхмүт Вәлиев сугышкан 120 нче танк бригадасы сугышчан юлының карта–схемасы күргәзмәгә куела. Икенче катта «Себер тракты тарихы», «Карадуган авылы тарихы» экспозицияләре бар. Почта элемтәсе тарихына караган экспонатлар арасында (1790 нан башлап) — ямщиклар киеме, ат дирбияләре, дуга кыңгыраулары, почта документлары үрнәкләре, 19 йөз хатлары, Казан губернасының 1797 елгы почта картасы, Казан өязенең 1887 елгы почта-телеграф округы картасы, Морзе аппараты, 20 йөз башы телефон аппараты, 1940 еллардагы почта хезмәткәрләренең форма






Карадуган авылында «Себер тракты тарихы» һәм Муса Җәлил музее.
1. Музей бинасы; 2. Экспозиция фрагменты: крәстиян хуҗалыгы һәм көнкүреше әйберләре. 20 йөз башы.

киемнәре, беренче совет телевизорлары. Экспозициянең Карадуган авылы тарихына багышланган бүлегендә төбәкне өйрәнү материаллары, музей урнашкан элеккеге йорт хуҗасының шәхси әйберләре, халык гамәли-бизәлеш сәнгате һәм этнография әйберләре куелган. Музейның аеруча кыйммәтле экспонатлары — М.Җәлилнең Мөбинә Таһировага бүләк иткән мандолинасы, Карадуган авылы мәктәбен оештыручыларның документлары һәм хөкүмәт бүләкләре, 20 йөз башы калфаклары. Музей ел саен Г.Тукай туган көнне (26 апр.), Җиңү көнен (9 май), Халыкара музейлар көнен (18 май), Татарстан Респ-касы көнен (30 авг.), Белем көнен (1 сент.) билгеләп үтә.

**СЕБЕ́Р ХАНЛЫГЫ́**, Көнбатыш Себердәге татар феодал дәүләте, 1420 еллар башында, Алтын Урда таркалганда һәм аның составыннан Шәйбани олысын аерганда барлыкка килә. Ханлыкка нигез салучы — *Хаҗимөхәммәд бәк*, ул Тура, Тубыл һәм Ишем елгалары буендагы җирләрне берләштерә. Башкаласы — Чыңгы-Тура, соңрак Кашлык шәһәре. С.х. биләмәләренә Иртеш б-н Тубыл елгалары буендагы, Бараба даласы, Обь буе җирләре керә. Халкы — җирле төркиләр һәм угор кабиләләре (соңрак угор кабиләләренең дә бер өлеше төркиләшә); алар күчмә тормышлы аксөякләргә (ханнар, карачибәкләр, тайбугалар, бәкләр һәм морзалар) һәм «кара халык»ка бүленә. Идарәче ыруглар — Мангыт, Җәлаир, Коңгырат, Сәлҗиут, Найман һ.б. Дәүләт дине — ислам. Халкы терлекчелек, игенчелек, аучылык һәм һөнәрчелек (балчык савыт-саба ясау, тире иләү, тукыма, келәм туку, металл эшкәртү) б-н шөгыльләнә, Урта Азия, Нугай Урдасы, Казан ханлыгы, Монголия, Көнбатыш Кытай һәм рус дәүләте б-н сәүдә итә. Ханлык терр-ясе *даругаларга* бүленә, аларда ханның җирле идарә башлыклары идарә итә. Халык ханга һәм җирле идарә башлыгына салым түли. Хаҗимөхәммәд Арал буена киткәннән соң, Себер аксөякләре баш күтәрә һәм *Әбелхәерне* хан итеп куя. 1430 елда аның гаскәрләре, җиңеп, Хаҗимөхәммәдне әсир алалар һәм җәзалап үтерәләр. Әбелхәер акрынлап идарә итү эшләрен Арал буенда җәелдерә һәм 1446 да башкаланы Сыгнакка күчерә. 1448 дә нугайлар Ваккас җитәкчелегендә, Әбелхәерне бәреп төшерәләр һәм С.х. б-н идарә итүне Ядегәргә тапшыралар. 1469 да *Ибакъ*, нугай морзалары Муса һәм Ямгырчы ярдәмендә, Төмән олысы җирләрен үзенә буйсындыра. Олы Урда ханы *Әхмәд хан* ярдәмендә алар Әбелхәер улы Шәех Хәйдәрне бәреп төшерәләр. Нәтиҗәдә, Күк Урдада сәяси таркалу барлыкка килә, һәм С.х. биләмәләре Көнбатыш Себергә рәсмиләштерелә. Ибакъ идарә иткән чорда ханлык бик куәтле була. Ибакъ Арал буендагы күчмә үзбәкләргә һәм Олы Урда ханы Әхмәдкә каршы тора. 1481 дә Ибакъ Муса һәм Ямгырчы б-н бергә Әхмәдне тар-мар итә. Шул ук елны ул бөек Мәскәү кенәзе Иван III б-н — сәүдә, 1483 тә дуслык һәм союз килешүе төзи. 1495 тә Ибакъ Мөхәммәд Тайбуга җитәкчелегендәге аксөякләр фетнәсе вакытында үтерелә. Соңгы хан Тубыл һәм Иртеш төбәкләрендәге татар олысларын берләштерә һәм Кашлык каласын (Сибир) үзәк итеп билгели. 16 йөз урталарыннан С.х.на руслар һөҗүме ешаю сәбәпле, Мөхәммәд Тайбуга нәселеннән булган *Ядегәр хан* 1555 тә үзен Рус дәүләтенең вассалы дип танырга мәҗбүр була. 1563 тә Шәйбанилар нәселе вәкиле *Күчүм хан* Тайбуга нәселеннән булган Ядегәр һәм Бикбулатны бәреп төшерә, С.х. тәхетен яулап ала. 1572 дә Урал буенда Рус дәүләтенә каршы көрәш башлый. Моңа җавап итеп С.х.на рус яулары оештырыла. 1581 дә рус сәүдәгәрләре һәм сәнәгатьчеләре Строгановлар ярдәмендә атаман Ермак Себергә яу оештыра, Күчүм ханны тар-мар итә һәм Кашлык шәһәрен басып ала. С.х. олысларга таркала. 1585 тә Ермак һәлак була, шулай да С.х.н рус дәүләтенә буйсындыру яулары дәвам итә (ныгытмалар төзү, төбәкне колонияләштерү). Күчүм хан үлгәннән соң (1598), С.х. тулысынча Рус дәүләтенә буйсындырыла.



СЕБЕР ХАНЛЫГЫ (1420–1590 еллар)

Чыг.: Сибирские летописи. СПб., 1907; Материалы по истории казахских ханств XV–XVIII вв. (Извлечения из персидских и тюркских сочинений). А.-А., 1969; История Казахстана в русских источниках XVI–XX веков: В 2 т. Алматы, 2005.

*Әд.:* Бахрушин С.В. Остяцкие и вогульские княжества в XVI–XVII вв. Л., 1935; Миллер Г.Ф. История Сибири. М.–Л., 1937. Т. 1; Скрынников Р.Г. Сибирская экспедиция Ермака. Новосиб., 1982; Сибирские татары. К., 2002; Файзрахманов Г.Л. История сибирских татар (с древнейших времён до начала XX века). К., 2002; Исхаков Д.М. Тюрко-татарские государства XV–XVI вв. К., 2004; шул ук. Введение в историю Сибирского ханства. К., 2006; Маслюженко Д.Н. Этнополитическая история лесостепного Притоболья в средние века. Курган, 2008. *И.Л.Измайлов.*

**«СЕБЕ́Р ЮКСЫЛЛАРЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Томск губерна ком-тының татар-кыргыз бюросы һәм РСФСР Милләтләр эшләре буенча Халык комис-тының губерна һәм Себер ревкомы каршындагы бүлек органы. 1919 елның 6 гыйнварыннан 1921 нең сентябренә кадәр Томск шәһәрендә татар телендә атнага 2 тапкыр нәшер ителә, барысы 24 саны чыга. 1920 дә «Кызыл Шәрекъ» исемендә басыла. Мөхәррире — Г.Абдуллин. Актив авторлары арасында — Ш.Багиров, Г.Габдуллин, М.Кадыйров, Г.Камский, А.Кормашев, Һ.Максуди, Г.Мирсәетов. Эчке һәм тышкы сәяси яңалыклар, хөкүмәтнең а.х. һәм сәнәгать үсешенә караган программалары нәшер ителә. РКП(б)ның 10 нчы съезды, Томск өлкәсе татар-кыргыз коммунистларының 2 нче конференциясе эшчәнлеге яктыртыла, җирле яшьләр оешмалары эше турындагы язмалар басыла. Әдәби сәхифәдә Ш.Бакиров, Г.Гали шигырьләре дөнья күрә.

**СЕБЕРКЕ́ КЫЯ́К** (Milium), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 6 төре билгеле, төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — салынкы С.к. (M.effusum) бар. Киң яфраклы һәм катнаш урманнарда үсә. 60–100 *см* биеклектәге тамыр-сабаклы күпьеллык кыяк. Сабагы шома. Яфраклары ачык-яшел, киң кыяклы, кырыйлары кытыршы. Чәчәк төркеме — җәенке себеркәч, озынлыгы 30–35 *см.* Җимеше — бөртекчә. Май–июньдә чәчәк ата. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н (куакны бүлеп) үрчи. Кумарин матдәле һәм хуш исле үсемлек. Мөгезле эре терлек яратып ашый, әмма терлек азыгы буларак әһәмияте юк. Декоратив үсемлек.

**СЕБЕРЧЕ́** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 17 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бөя елгасы буенда. 2010 елда 15 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.дә Михаил-Архангел чиркәве, земство мәктәбе (1888 дә ачыла), 1 җил һәм 2 су тегермәне, тимерчелек, ярма яргыч, 2 вак-тояклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1526,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Шәмбалыкчы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 153 ир-ат; 1859 да — 554, 1897 дә — 798, 1908 дә — 986, 1920 дә — 717, 1926 да — 578, 1938 дә — 304, 1949 да — 216, 1958 дә — 100, 1970 тә — 47, 1979 да — 37, 1989 да — 25, 2002 дә — 25 кеше.

**СЕВАСТЬЯ́НОВ** Валерий Иванович (17.9.1943, Казан), кинооператор, ТАССР һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1976, 1996). Бөтенсоюз дәүләт кинематография ин-тының кинооператорлар ф-тын тәмам-

лый (1972, Б.И.Волчек остаханәсе). 1963 елдан Казан кинохроника студиясендә, кинооператор А.С.Стремяков ассистенты, 1972 дән кинооператор. С.ның беренче мөстәкыйль хезмәтләре үк материалны бирүдә зур осталыгы, кадрларның төгәллеге һәм сәнгатьлелеге, көтелмәгән һәм кыю ракурслар ала белүе б-н билгеләп үтелә. 1972 дән гарәп Көнчыгышы турында «Асуан гидроэнергетика төйнәлеше» («Асуанский гидроэнергетический узел»), «Табок төзелеше дәвам итә» («Строительство Табка продолжается»), «Евфратны ябу» («Перекрытие Евфрата») фильмнары циклын төшерә. «Кара туфраклы булмаган җирләр. Мордовия. Юл башында» («Нечерноземье. Мордовия. В начале пути») фильмы Бөтенсоюз кинофестивале призына лаек була (1978). «Тукай» (1969), «Казан» (1973), «Образның тууы» («Рождение образа», 1980), «Рәссам Иван Шишкин» («Художник Иван Шишкин», 1982), «Килеп чыкмаган очрашу» («Несостоявшаяся встреча», 1988), «Яшәешнең иң югары ноктасы» («Вершина бытия», 1989) фильмнары С.ны дөньяны поэтик күзаллаучы иҗат остасы буларак ача. «Бу — КамАЗ» («Это — КамАЗ», 1982), «Үземне мин кызгана белмим...» («Себя жалеть я не умею...», 1989), «Мари-Чодра» (1991) фильмнарында ул режиссёр-оператор буларак чыгыш ясый. 1964–83 тә Казан кинохроника студиясендә 50 дән артык документаль һәм фәнни-популяр фильмнар, Мәскәүдәге Үзәк документаль фильмнар студиясендә «Көн яңалыклары» («Новости дня»), «Фитиль», «Советлар Союзына хезмәт итәм» («Служу Советскому Союзу») киножурналлары өчен сюжетлар төшерә. 1983–87 дә — Одесса нәфис фильмнар студиясендә («Одесса батырлыгы» — «Подвиг Одессы», 1985, СССР Дәүләт бүләге; «Канат җәйгәндә» — «Размах крыльев», 1986), 1987 дән Свердловск киностудиясендә («Кара һәм ак тылсым» («Магия чёрная и белая», 1989), «Калмык каны тамчысы» («Капля калмыцкой крови», 1990) документаль фильмнары; «Минем сөекле сары чыпчыгым» («Мой милый чиж», 1991) нәфис фильмы һ.б.) эшли. С. оператор сыйфатында режиссёрлар А.Учитель («Сизү көче буларак космос» — «Космос как предчувствие», 27 нче Мәскәү халыкара кинофестивалендә төп приз һәм операторлык осталыгы өчен «Ника» призы, икесе дә — 2004), С.Говорухин («Бер икмәк белән генә түгел» — «Не хлебом единым», 2005, «Европага ачык тәрәзә» — «Окно в Европу» Россия киносының 13 нче фестивалендә төп приз һәм 12 нче Минск халыкара фестивалендә иң яхшы операторлык эше өчен приз), А.Ихо («Кружовник»), С.Соловьёв («Анна Каренина»), М.Мигунова («Сөяркәләр» — «Любовники») (барысы да — 2006) фильмнарын; режиссёрлар Г.Николаенко («Намус кодексы — 2» — «Кодекс чести — 2», 2004) һәм Ю.Мороз («Ванюхин балалары» — «Дети Ванюхина», 2005) сериалларын төшерә. А.Учительнең «Әсир» («Пленный») һәм С.Говорухинның «Пассажир хатын-кыз» («Пассажирка», икесе дә — 2007) (Ю.Клименко б-н берлектә), ш.у. режиссёр А.Прошкинның «Могҗиза» («Чудо», 2008) фильмнары операторы.

*Е.П.Алексеева.*

**СЕВАСТЬЯ́НОВА** Лидия Антоновна (24.3.1928, Алтай краеның хәзерге Славгородский р-ны Ново-Алексеевка а.), селекция белгече һәм җимеш культуралары биологы, а.х. фән. канд. (1955), РФнең атказ. агрономы (1996). Томск ун-тын тәмамлаганнан соң (1951), Мичурин җиләк-җимеш-яшелчә ин-тында эшли. 1955–62 елларда СССР ФА Себер бүлегенең Үзәк ботаника бакчасында (Новосибирск ш). 1962–95 тә Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының бакчачылык бүлегендә. Чия һәм сливаның 24 сорты авторларының берсе, шулардан ТРда районлаштырылганнары: чия сортлары — «Краса Татарии», «Заря Татарии», «Түбән Кама», «Обильная», «Севастьяновская», «Труженица Татарии», «Тверитиновская», «Шакиров»; слива сортлары — «Тәмте Ренклоды», «Казан», «Теньковская синяя», «Ракета», «Сверхранняя», «Волжанка», «Память Ханова», «Татарская жёлтая», «Теньковская голубка». Уйлап табуга 14 авторлык таныклыгы бар. С. Урта Идел шартларында җимеш культураларының органогенезы һәм салкынга чыдамлылыгы үзенчәлекләрен өйрәнүгә өлеш кертә, иртә үсеш стадиясендә чия һәм слива гибрид чәчкеннәренең кышка чыдамлылыгын билгеләүне эшли. Медаль б-н бүләкләнә, «СССР уйлап табучысы» билгесе бирелә.

Х е з м.: Новое в садоводстве. К., 1977 (автордаш); Совершенствование сортимента вишни // Проблемы развития садоводства и ягодоводства в Татарии. К., 1981.

*Әд.:* Садоводы — учёные России: Краткий биогр. справ. Орёл, 1997.

**«СЕВАСТЬЯ́НОВСКАЯ»**, чиянең уртача соң өлгерешле десерт сорты. Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында 1990 елда Л.А.*Севастьянова* һәм В.А.*Наумов* тарафыннан «Тверитиновская» сортыннан ирекле серкәләндерү юлы б-н чыгарыла. Бу сорт югары уңышлы, салкынга чыдам, җимешләре тәмле. Куагы биек түгел, күп яфраклы озынча ябалдашлы. Сабаклары як-якка таралган, очлары өскә таба юнәлгән, кайрысы көрән төстә, алтынсу төсмерле. Үрентеләре нечкә, азрак бөгелгән, соры куныклы көрән төстә. Яфраклары уртача зурлыкта, озынча, очлы, шома, читләре азрак тешле. Төпчек яфраклары уртача зурлыкта, иртә коелучан. Яфрак сабы кыска, пигментлашкан. Чәчәкләре уртача зурлыкта, ак төстә. Таҗлары озынча, кушылмаган. Бер чәчәк төркемендә 5–11 чәчәк. Җимешләре уртача зурлыкта (3,7–4,5 *г*), озынча, конуссыман, ялтырый торган, кара-кызыл төстә. Үзлегеннән җимеш бирүчәнлеге югары түгел. Коккомикозга чыдамлыгы уртача. Иң яхшы серкәләндерүчеләре — «Тверитиновская», «Маяк», «Уральская рубиновая», «Шакиров» сортлары. «С.» яшел чыбыкчалардан һәм гади чия чәчкеннәренә бөре ялгау б-н яхшы үрчетелә. Татарстанда 1998 дән районлаштырылган. Нигездә, кумәк һәм йорт яны бакчаларында үстерелә.

*Әд.:* Фруктовый сад Татарстана. К., 2005.

*В.А.Наумов, Л.А.Севастьянова.*

**СЕ́ВЕРНЫЙ РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1957 елның 14 гыйнварында оештырыла. Мәйданы — 2,1 мең *км*$^2$. Үзәге — Северное авылы (Оренбургтан 586 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 13697 кеше (2013). Татарлар саны: 1970 тә — 4698, 1979 да — 4173, 1989 да — 3765, 2002 дә — 3349, 2010 да — 2717 кеше. Алар, башлыча, Бакай, Керәжле, Ибрай авылларында, Тургай, Яктыкүл, Зирекле посёлокларында яшиләр. Район терр-ясенә татарлар 1740 елларда күченәләр. Бакай авылы шул чордан (1740 тан) билгеле. Хәзерге вакытта бу авылда «Асылъяр» җыр ансамбле һәм «Шатлык» татар балалар театры эшли. Бакай һәм Керәжле урта мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укытыла. Районда *Сабан туе* даими уздырыла.

*Әд.:* Ф а р з у т д и н о в Р. Земля отцов. Бугульма, 2008.

**СЕВРЮ́ГИН** Вячеслав Анатольевич (4.3.1950, Киров өлкәсенең Санчурск пос.), физик, физика-матем. фән. д-ры (2002), проф. (2004), Мари Респ-касының атказ. фән эшлеклесе (2001), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). 1972 елда Мари пед. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 2008 дән Мари ун-тының физика каф. профессоры. Хезмәтләре сыек фазадагы молекуляр система компонентларының трансляция хәрәкәте динамикасын тикшерүгә карый. С. беренче булып магнит кыры импульсы градиентлы ТМР алымнары ярдәмендә сахаридларның судагы эремәләрендә һәм электролит эремәләрендә протон алмашу күренешен ача (бергәләп), лабиль халәтләрдәге протоннарның яшәү вакыты бүленеше функциясен таба. Сыегайтылган эремәләрдә компонентларның үздиффузия коэффициентларының концентрациягә бәйлелеген аңлатуның бердәм фәнни юлын күрсәтә. Дәүләт бүләге катлаулы молекуляр системаларның структурасын һәм динамикасын тикшерүдә градиентлы ТМР алымнарын үстерүгә караган хезмәтләре өчен бирелә.

Х е з м.: Обменные процессы в водных растворах сахаридов // Журн. физ. химии. 1998. Т. 72, № 5 (автордаш); Трансляционная подвижность молекул воды и ионов $Li^+$, $F^-$, $Al^{3+}$ в водных растворах LiCl, KF и $Al(NO_3)_3$ // Журн. физ. химии. 1999. Т. 73, № 3 (автордаш); Concentration dependences of solvent Self-Diffusion Coefficients in Solutions and heterogeneous Systems // Applied Magnetic Resonance. 2005. V.29, № 3 (автордаш).

**СЕДЕ́ЛЬНИКОВ** Юрий Евгеньевич (2.1.1942, Үзбәкстан ССРның Фирганә ш.), радиоэлектроника өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1996), проф. (1999), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2004). 1965 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, радиоидарә каф. профессоры (1996 дан), бер үк вакытта «Сокол» тәҗрибә-конструкторлык бюросының баш белгече (2005 тән). Хезмәтләре махсус радиотехник системаларга карый. 200 дән артык фәнни хезмәт авторы. Уйлап табуга 41 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар.

Х е з м.: Низкоинтенсивные СВЧ-технологии. М., 2003 (автордаш); Электромагнитная совместимость радиоэлектронных средств. К., 2006.

**СЕДМИОЗЁРНЫЙ БОГОРО́ДИЦА ПУ́СТЫНЕ**, Биектау р-ның Семиозёрка авылындагы ирләр монастыре. Бөек Устюг шәһәреннән килгән инок Евфимий тарафыннан 1615 ел тирәсендә нигез салына. Монастырьның күтәрелеш чоры Седмиозёрный Смоленский Мәрьям Ана иконасының 17 йөз уртасында шөһрәт казануы б-н бәйле (к. *Икона*). Элек монастырь биналары агачтан төзелә. 1645 тә таштан Вознесение чиркәве, 1668 дә — Смоленский соборы, 19 йөзнең 2 нче яртысында — ике катлы таш корпуслар комплексы; 1879 да 64 *м* биеклектәге чаң манарасы, 19 йөз ахырында капкалы яңа диварлар төзелә. 20 йөз башына С.Б.п. үзенчәлекле архит-ра комплексын тәшкил итә. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында схиархимандрит *Гавриил* (Зырянов) җитәкчелегендә монастырь алга киткән а.х. пр-тиесенә әверелә, биредә заман таләбе югарылыгында кырчылык, терлекчелек, умартачылык үсеш ала, а.х. продукциясен эшкәртү тормышка ашырыла. 1927 дән, монастырь ябылганнан соң, аның терр-ясендә халык мәгарифе учреждениеләре урнаша; корылмаларның күпчелеге сүтелә. 1990 еллар уртасына рус-Византия юнәлешендәге эклектика стиле архит-ра истәлеге булган (1899–1900, арх.



Седмиозёрный Богородица пустыне.
Гомуми күренеше. 20 йөз фоторәсеме.


Ф.Н.Малиновский) Евфимий Великий һәм Тихон Задонский храмы һәм ике катлы таш борадәрлек корпусы (1893) сакланып кала. 1997 дән монастырь яңадан эшли башлый, 2000 дә храм реставрацияләнә. Изге Гавриил сөякләре саклана.

*Әд.:* Сказание о Седмиозёрной Богородицкой пустыни... К., 1893; Старец схиархимандрит Гавриил (Зырянов) и Седмиозёрная Казанская Богородичная пустынь. М., 1991; Республика Татарстан: Православные памятники. К., 1998.

*Е.В.Липаков, Х.Г.Надыйрова.*

**СЕДО́В** Александр Осипович (15.8.1911, Уфа губ., Минзәлә өязе Ширәмәт а. — 23.8.1999, Яшел Үзән ш.), слесарь, Соц. Хезмәт Герое (1966). Чистай шәһәрендә слесарьлар курсын тәмамлый (1931). 1931–83 елларда А.М.Горький исем. Яшел Үзән з-дында эшли, слесарьлар бригадиры (1932 дән). «Алтын куллы оста», «Иң яхшы рационализатор» исемнәренә лаек була. С.ның рационализаторлык тәкъдимнәре диңгездә балык тоту судноларында файдаланыла торган «АСМА» балык туңдыру агрегатын реконструкцияләүдә һәм модернизацияләүдә кулланыла. Герой исеме жидееллык (1959–65) планны үтәгәндә ирешкән уңышлары һәм яңа техника булдырганы өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. С.ның исеме респ-ка Мактау китабына кертелә (1967).

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.



А.О.Седов.

**СЕЖЕ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 25 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кесмәс елгасы буенда. 2010 елда 279 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Мурья Мусич исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 630,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 58 ир-ат; 1859 да — 304, 1897 дә — 540, 1908 дә — 610, 1920 дә — 748, 1926 да — 615, 1938 дә — 722, 1949 да — 569, 1958 дә — 544, 1970 тә — 443, 1979 да — 340, 1989 да — 277, 2002 дә — 293 кеше.

**СЕЙ́Н** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Кибәче елгасының (Мишә елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 16,1 *км*, бассейнының мәйданы 98 $км^2$. Питрәч р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Яңа Белкино (даими яшәүчеләр юк) авылы янында, Урывкино авылыннан 3 *км* төньяктарак, тамагы Кибәче авылында. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 75 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. С.нең 1,6 дан 5,4 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,63 $км/км^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 140 *мм*, ташу агымы катламы 130 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,022 $м^3/с$. Җәен елганың аерым урыннары кибә. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. С. бассейнында суының гомуми күләме 2,6 млн. $м^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**СЕЛӘУСЕ́Н** (Felis lynx), мәчесыманнар семьялыгыннан имезүче ерткыч хайван. Евразия, Төньяк Американың урман массивларында таралган. Татарстан терр-ясендә Кама алдында һәм Кама аръягында, яшь агачлар һәм куаклар күпләп үскән, ауган агачлары булган биек кәүсәле урманнарда очрый. Күчмә яшәү рәвеше алып бара. Үрчү чорында бер урында гына яши. Озынлыгы 100 *см* дан артык, авырлыгы 14–23 *кг*. Гәүдәсе кыска, тыгыз, киң йөнтәс тәпиле аяклары озын, көчле. Башының ян-ягындагы озын йоннары — «чигә сакалы», колак очларында чуклар хасил итәләр. Койрыгы кыска. Кышкы йоны бик озын һәм йомшак, җәйгесе — кыска һәм тупас. Җирән, коңгырт, соры, кара тимгелле һәм буйлы җирән-коңгырт яки соргылт-тонык сары төстә. Агачларга җиңел үрмәли, яхшы йөзә. Өне — чокырларда, иске җәнлек ояларында. Куышу чоры февраль–мартта. Балалары (гадәттә, 2–3) апрель–июньдә туа. Җенси җитлегү чоры — яшәвенең 2–3 нче елында. Нигездә, куяннар, ш.у. көртлек кошлар (божырлар, көртлекләр), кыр тычканнары б-н туклана. С.нең төп дошманнары — бүре, комагай. Мехы югары бәяләнә, әмма аз санда булганлыктан, С.нең кәсәбәчелек әһәмияте зур түгел.

**СЕЛЕЗНЁВ** Владимир Андреевич (5.12.1937, Чиләбе өлкәсенең Златоуст ш. — 5.6.2006, Казан), физик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1998), физика-матем. фән. канд. (1976). Сәмәркәнд ун-тын тәмамлый (1961), Федераль ГИПО ФҖБ дәүләт унитар пр-тиесендә эшли, әйдәп баручы инженер (1971–75), лаб. башлыгы (1975–87), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1987 дән). Хезмәтләре интерферометриягә, голограммалы оптик элементларга карый. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге голограммалы дифракцион рәшәткәләр әзерләүнең фәнни технологиясе нигезләрен эшләүдә һәм аны ГИПОның серияләп дифракцион оптика җитештерүенә кертүдә катнашканы өчен бирелә (Россия тармак пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә). Медаль б-н бүләкләнә.

**СЕЛЕ́КЦИЯ** (лат. selectio — сайлап алу), 1) үсемлекләрнең сортларын, гибридларын һәм хайваннарның токымнарын булдыру алымнарын эшли торган фән; 2) а.х. культураларының сортларын, гибридларын һәм хайваннарның токымнарын чыгару б-н шөгыльләнә торган а.х. тармагы. Үсемлекләр С.се берничә юнәлешкә аерыла: уңышка С. (С.дә төп юнәлеш); сыйфатка С. (файдалы матдәләрнең күп, файдасыз кушылмаларның аз булуы, эшкәртү өчен яраклылыгы, җимешләрнең, яшелчә, бәрәңге, тамыразыкларның яхшы саклануы); салкынга, корылыкка С., авыруларга һәм корткычларга каршы торучанлыкка С., механикалаштырып үстерүгә яраклылыгы, җирле климат һәм агротехник шартларга җайлашуга С. Хайваннар С.сендәге төп юнәлешләр: сөт терлекләренең сөт аксымын күтәрүгә, мөгезле эре терлекләрнең ит токымында һәм дуңгызларда майлылыкны киметүгә һәм ит чыгышын арттыруга, сарыклардан йон алуга, тавык йомыркаларының авырлыгын арттыруга, заманча җитештерү

технологияләре шартларына җайлашуга С. һ.б.

С. кешегә кирәкле юнәлештә үсемлекләр һәм хайваннарның нәсел сыйфатларын үзгәртү максаты б-н аларга тәэсир итү ысулларын эшли. Ул үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы эволюциясе формаларының берсе булып тора, табигатьтә төрләр эволюциясе буйсынган законнарга буйсына; әмма табигый сайлап алу монда өлешчә ясалма сайлап алу б-н алыштырыла, шул С. эшенең нигезен тәшкил итә, үзлекләр һәм билгеләр комплексы буенча алып барыла. Үсемлек һәм хайваннарны индивидуаль сайлап алу нигезендә чиста линияләр, гомо- һәм гетерозиготлык, фенотип һәм генотипның тәңгәлсезлеге турындагы генетик күзаллаулар ята.

Мөстәкыйль рәвештә нәселдән килгән һәм ирекле кушылу билгеләре закончалыклары нәселдә (токымда) гибридлаштыру һәм катнаш кушылдыруның теоретик нигезе булып тора. Гибридлаштыру беренчел материалны ясалма булдыру, бер организмда башлангыч формаларының билгеләрен һәм үзенчәлекләрен берләштерү, хайван токымнарын һәм үсемлек сортларының аерым җитешсезлекләрен төзәтү мөмкинлекләрен бирә. Гибридлаштыру алымы һәм аннан соңгы сайланыш б-н а.х. культураларының күп заманча сортлары чыгарыла (к. *Үсемлек сортлары*). Гетерозис күренеше беренче буында югары продуктлылыкка ия булган гибридлар алырга мөмкинлек бирә. Ул кыяр, томат, кукуруз С.сендә киң кулланыла. Полиплоидлар ярдәмендә (нәселдән килгән үзгәрүчәнлек, үсемлек күзәнәкләрендә хромосомалар саны арту б-н бәйле) хромосомалар саны арту б-н полиплоид үсемлекләр алалар (триплоидлар, тетраплоидлар), алар гади үсемлекләрдән (диплоидлы) куерак төсләре, калын яфраклары һәм сабаклары, көчле үсеше б-н, аксым, шикәр, крахмалның күп булуы б-н аерылалар. Полиплоидия куллану нигезендә арыш, клеверның югары уңыш бирә торган сортлары чыгарыла. Ясалма мутагенез — С.нең перспективалы алымнарыннан берсе.

Мутация (нәселдәнлегә үзгәрү) орлыкларны һәм үсемлекләрне төрле төрдәге нурлар, химик матдәләр б-н эшкәрткәндә килеп чыгарга мөмкин. Мутантлар арасында бер үк вакытта берничә үзлеге файдалы үзгәрешле формалары еш очрый. Хайваннар С.сендә заманча генетик алымнар: популяцияләр генетикасы һәм иммуногенетика киң кулланыш таба. Россиядә фәнни селекция үсешенең башлангычы 1903 еллардан — Мәскәү а.х. ин-ты (хәзер К.А.Тимирязев исем. Мәскәү а.х. академиясе) каршында Д.Л.Рудзинский тарафыннан селекция станциясе оештырылган вакыттан санала, бу станциядә илдә беренче тапкыр бөртекле культуралар һәм җитеннең сортлары чыгарыла. 1920–30 елларда яңа фәнни-тикшеренү селекция учреждениеләре челтәре булдырыла, генетик һәм селекция тикшеренүләре җәелдерелә.

Татарстанда селекция тикшеренүләре *Казан авыл хуҗалыгы тәҗрибә станциясендә* И.И.Штуцер җитәкчелегендә (1920–30) башлана, Югары Идел буе селекция үзәгендә (1931–35), *Казан селекция станциясендә* (1936–46), *Татарстан республика авыл хуҗалыгы тәҗрибә станциясендә* (1947–69), *Татарстан авыл хуҗалыгы институтында* (1969 дан) дәвам иттерелә. Татарстан а.х. ин-ты эшләгән елларда селекционерлар тарафыннан а.х. культураларының 96 сорты чыгарыла. 1938 дән алмагач һәм төшле культуралар (к. *Бакчачылык*) буенча С. алып барыла. Хәзерге вакытта С. б-н шөгыльләнүчеләр — В.И.Блохин (арпа), Н.З.Василова (язгы бодай), Ф.З.*Кадыйрова*, Л.Р.Кадыйрова (карабодай), И.Ю.Никифорова (тары), Г.Е.*Осипов* (җимеш культуралары), С.Н.*Пономарёв* (тритикале), М.Л.*Пономарёва* (көзге арыш), А.Н.*Фадеева* (борчак), И.П.Фадеева (көзге бодай). А.х. культуралары селекциясенә ш.у. фермерлык селекция-орлыкчылык хуҗалыгы башлыгы Э.Ф.*Ионов* зур өлеш кертә. ТРда җирле селекция сортларының чагыштырма өлеше карабодай буенча 100%, көзге бодай — 86%, көзге арыш — 80%, арпа буенча 44% тәшкил итә. ТРның С. сортлары сортлап районлаштыру буенча РФнең 8 (12 дән) икътисади регионында Дәүләт реестрына кертелгән. Ш.у.к. *Агрономия*.

*Әд.:* Вавилов Н.И. Избр. соч. М., 1966; Лукьяненко П.П. Избр. труды. М., 1973; Татарскому научно-исследовательскому институту сельского хозяйства «Нива Татарстана» — 80 лет // Нива Татарстана. 2000. № 3.

*Р.Р.Муллахмәтова.*

**СЕЛЕНИ́Т**, к. *Гипс*.

**СЕЛЕНОДЕ́ЗИЯ** (грек. Selḗnē — Ай һәм dáiō — бүләм), планетологиянең бер бүлеге; Ай инерциясе эллипсоидын, селеноид параметрларын (авырлык көче һәм өслек нигезләмәләре), Айның массалар үзәгенә һәм төп инерция күчәрләренә карата ай өслегенең турыпочмаклы сферик координаталарын, өч үлчәнешле геометрик җисем буларак Айның фигурасын һәм үлчәмнәрен өйрәнә; Ай өслегенең картографиясен, гипсометрик рельеф карталарын төзи, Айның геометрик һәм динамик фигураларын планетар масштабта өйрәнә. С.нең фәнни дисциплина буларак яши башлавы Ай өслеген беренче тапкыр телескоптан күзәткән Галилей хезмәтләре б-н бәйле.

Казанда С. буенча тикшеренүләрне Д.И.*Дубяго* тырышлыгы б-н 1895 елда А.В.Краснов башлап җибәрә. Айның әйләнү характерын, аерым алганда, Айның физик либрациясен (АФЛ) өйрәнү максатында айның күренмә ягына карата Местинг А кратерының гелиометрик үлчәмнәре алына. Бу эшләр башта — Казан шәһәр астрономия, ә 1910 нан Энгельгардт астрономия обсерваторияләрендә алып барыла (А.В.Краснов, А.А.Михайловский, Т.А.Банахевич, А.А.Яковкин, И.В.Белькович, А.А.Нефедьев). Яковкин һәм Белькович, гелиометрик күзәтү алымнарын үстереп, Ай фигурасы һәм АФЛ турында яңа мәгълүмат алалар. Нефедьев Айның кырый зонасы нокталарының биеклекләр картасын төзи. Ш.Т.Хәбибуллин АФЛн фотографик күзәтүләр буенча өйрәнә һәм аны тикшерүнең яңа ысулларын үстерә, селенографик координаталарга анализ ясый һәм Ай картографиясен теоретик яктан нигезли, Айның әйләнү күчәре прецессиясе һәм нутациясе теориясен үстерә, беренче булып АФЛнең нәсызыкча теориясен тәкъдим итә һәм ш.у. селеноид фигурасын ачыклау мәсьәләсен карый, Айның гравитацион аномалияләре картасын һәм өслеге тигезләмәләрен төзи. В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясендә, беренче булып, Айның масса үзәгенең аның фигурасы үзәгенә карата Җиргә 3,3 *км* га якынрак урнашуы ачыклана (К.С.Шакиров), Айның һәм йолдызларның зур масштаблы сурәтләре алына һәм алар нигезендә күп кенә мәсьәләләр хәл ителә (Н.Г.Ризванов). 1959 га кадәр С. мәсьәләләре Айның күренмә ягын Җирдән астрономик күзәтүләр юлы б-н хәл ителә. Космик ракеталар техникасының үсеше Айның күренмә һәм кире якларын аның тирәсендәге космик фәзада һәм өслегендә үк күзәтү мөмкинлеген бирә. Нефедьев җитәкчелегендә «Зонд-6» һәм «Зонд-8» космик аппаратларыннан алынган рәсемнәр нигезендә Айның кире ягы рельефы өйрәнелә.

*Әд.:* Нефедьев А.А. Карты рельефа краевой зоны Луны // Изв. Астрон. обсерватории им. В.П.Энгельгардта. 1958. № 30; Фигура Луны и проблемы лунной топографии. М., 1968; Habibullin Sh.T., Rizvanov N.G. Independent selenocentric system of coordinates // Earth, Moon and Planets. 1984. V. 30, № 1.

*Н.Г.Ризванов.*

**СЕЛИВА́НОВ** Александр Васильевич (17.11.1918, Рязань өлкәсенең Ухолово р-ны Борисовка а. — 2007, Мәскәү), эпизоотолог, вет. фән. д-ры (1964), проф. (1965), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1978). Хәрби-вет. академиясен тәмамлый (Мәскәү, 1941). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946–47 елларда Сов. Армиясенең 4 нче аерым укчы бригадасында бригада вет. табибе. 1947–57 дә Бөтенсоюз экспериментал ь вет. ин-тында. 1952–66 да Себер фәнни-тикшеренү вет. ин-тында (Омск ш.) директор урынбасары. 1966–73 тә Казан вет. ин-ты проректоры. 1974 тән Бөтенсоюз вет. препаратларына контрольлек итү фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү): аэрозольле вет. препаратларына контрольлек итү лаб-ясе мөдире (1974–76, 1983–90), директор урынбасары (1976–93), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1990–2007). Фәнни тикшеренүләре терлекләрдәге йогышлы авыруларны кисәтүнең төркемле (аэрозольле, перораль) ысулларын эшләү өлкәсенә карый. С. листериозга, Ауески авыруына, чәшкеләрдәге псевдомоноз һәм вируслы энтеритка каршы вакцина куллануны гамәлгә кертә, затлы мехлы җәнлекләр һәм этләрдәге төп йогышлы авыруларга каршы вакциналарны чагыштыра. СССР МС бүләге лауреаты (1980). 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: О системе ветеринарно-санитарных мероприятий в крупных специализированных животноводческих хозяйствах мясного и молочного направления // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1970. Т. 107 (автордаш); Групповая профилактика инфекционных болезней животных. М., 1983 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*Р.Г.Госманов, К.Х.Папуниди.*

**СЕЛИВА́НОВА** Августа Степановна (27.8.1923, Чиләбе өлкәсенең Троицк ш. — 17.5.2007, Мәскәү), вет. фармакологы, вет. фән. д-ры (1968), проф. (1970). Троицк вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1946), Мәскәү вет. академиясендә эшли. 1950–67 елларда (бүленеп) Себер фәнни-тикшеренү вет. ин-тында (Омск ш.), 1953–57 дә Омск вет. ин-тында. 1967–74 тә Казан вет. ин-тының химиотерапия лаб-ясендә химик препаратларны беренчел сынау бүлеге мөдире. 1974 тән Бөтенроссия дарулар һәм азыкларның сыйфатын тикшерү һәм стандартлаштыру үзәгендә (Мәскәү). Фәнни тикшеренүләре а.х. терлекләренең йогышлы һәм йогышлы булмаган авырулары очракларында дәвалау-профилактика чаралары эшләү өлкәсенә карый. СССР МС бүләге лауреаты (1980).

Х е з м.: Кумулятивные свойства хлорофоса и его аналогов // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1970. Т. 107 (автордаш); Электрофоретическая картина сыворотки крови кур при действии хлорофоса // шунда ук.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*К.Х.Папуниди.*

**СЕЛИВАНО́ВСКАЯ** Светлана Юрьевна (3.10.1957, Казан), микробиолог, эколог, биол. фән. д-ры (2004), проф. (2006). Казан ун-тын тәмамлый (1980), шунда ук эшли. Хезмәтләре биотехнол. һәм микробиол. экологиясенә карый. С. табигый һәм ясалма экосистемаларда микроб бергәлекләре яшәешенең фәнни нигезләрен тикшерә. Агынты сулар утырмаларының табигый тирәлеккә йогынтысын бәяләү һәм нормага салу юлларын нигезли. Уйлап табуга 1 патенты, 2 авторлык таныклыгы бар. ТР ФАнең В.А.Попов исем. бүләге лауреаты. Суларны чистарту алымнарын эшләгәне өчен, СССР ВДНХсының бронза медаленә лаек була.

Х е з м.: Региональное нормирование антропогенных нагрузок на природные среды. К., 2002 (автордаш); Создание тест-системы для оценки токсичности многокомпонентных образований // Экология. 2004. № 1 (автордаш); Микробиологические процессы в серой лесной почве, обработанной компостом из осадка сточных вод // Почвоведение. 2006. № 4 (автордаш).

**СЕЛИВАНО́ВСКИЙ** Борис Владимирович (6.10.1907, Вятка губ., Яранск өязенең Кикнур а. — 14.8.1972, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1954), проф. (1955). Казан ун-тын тәмамлый (1930), шунда ук эшли (1934 тән), палеонтология һәм тарихи геол. каф. мөдире (1954–66). Хезмәтләре Идел-Урал төбәгенең стратиграфиясе, файдалы казылмалары, тектоникасы һәм геоморфологиясенә карый. С. Татарстан һәм чиктәш регионнар терр-ясендә геол. төзелеш, тектоника, стратиграфия, файдалы казылмаларның урнашу, карст процесслары үзенчәлекләрен тасвирлый. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Верхнеказанские отложения центральной части Волжско-Камского края // Докл. АН СССР. 1953. Т. 90, № 4 (автордаш); О карстовых процессах и карстовых формах в Среднем Поволжье // Региональное карстоведение. М., 1961. Т. 3.

**СЕ́ЛИЩЕ ГОВЯ́ДИНО** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 11 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сәкел елгасы буенда. 2010 елда 11 кеше (руслар) яши. 1647–52 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Селищи, Говядина исемнәре б-н дә билгеле. Халкы башта Зөя Успение Богородица монастырена карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 4 тегермән, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 669 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Шырдан волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 151 ир-ат; 1859 да — 742, 1897 дә — 768, 1908 дә — 559, 1920 дә — 540, 1926 да — 569, 1938 дә — 617, 1949 да — 310, 1958 дә — 280, 1970 тә — 188, 1979 да — 152, 1989 да — 31, 2002 дә — 20 кеше.

**СЕЛИ́ЩЕВ** Афанасий Матвеевич (11.1.1886, Орёл губ., Ливенский өязе Волово а. — 6.12.1942, Мәскәү), тел галиме, СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1929). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1910), шунда ук эшли; Казан югары хатын-кызлар курсларында славян филологиясе укыта. 1914 елда, көньяк славян телләрен өйрәнү өчен, Болгария, Македония, Албаниягә командировкага җибәрелә; шул сәфәрнең нәтиҗәсе буларак, «Македония диалектологиясе буенча очерклар» («Очерки по македонской диалектологии», 1918) монографиясен бастырып чыгара. 1918–20 дә Иркутск ун-ты профессоры; Себер рус сөйләшләрен өйрәнү б-н шөгыльләнә. 1920 дән Казан ун-ты профессоры; славян булмаган халыклар (чуашлар, чирмешләр) арасында рус теленең таралышын өйрәнә. 1922 дән Мәскәү ун-тында: проф., славян филологиясе каф. мөдире. Бер үк вакытта Мәскәү диалектология комиссиясендә эшли, иҗтимагый фәннәр фәнни-тикшеренү ин-тларының Россия ассоциациясе әгъзасы була. 1933 тән СССР ФАнең Славяннлык ин-тында. 1934 тә «Россия милли партиясе эше» буенча кулга алына, 5 елга лагерьга хөкем ителә. Вакытыннан алда иреккә чыгарылганнан соң (1937), Мәскәү тарих, философия һәм әдәбият ин-тында эшли, 1939 дан — Мәскәү шәһәр пед. ин-тында, Фин-угор җәмгыяте академиясе (Хельсинки, 1926), Болгария ФА мөхбир әгъзасы (1930). Македония фәнни җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы.

Х е з м.: Введение в сравнительную грамматику славянских языков. К., 1914; Избр. труды. М., 1968.

*Әд.:* Памяти Афанасия Матвеевича Селищева: Сб. статей и докл. Елец, 2003.

*Л.К.Бәйрәмова.*

**СЕЛТЕ́-ПОТА́Ш КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́**, көлдән поташ-калий карбонаты (углекислый калий) алу. Борынгы заманнардан билгеле. Казан губернасында 17 йөз ахырларында теркәлгән. Зөя өязендә һәм башка кайбер өязләрдә киң таралган. Хезмәт артельгә җыелып башкарылган. 19 йөздә Селте-поташ һәм урманга бәйле химия кәсепчелеге б-н 3 меңнән артык кеше шөгыльләнә. Поташ постау, сабын, яхшы сыйфатлы пыяла һәм буяу җитештергәндә, тире эшкәрткәндә кулланылган. Аны алу өчен башта — агач, сирәк очракта үлән һәм карабодай саламын (аның продуктлылыгы зур булган) яндырып, көлне чаннарда чылаталар, суын парга әйләндерәләр һәм мичтә кыздыралар. Поташ алуның берничә ысулы арасында иң борынгы — «Казан ысулы» аерылып торган. «Казан шадригы» дип аталган югары сыйфатлы поташ юеш ысул б-н кыздырып табылган: урман аланында 150–200 пот көл җыелырлык итеп агач яккannar. Көл суынгач, аны кырыйга эттереп, учак урынына 3–4 коры усак яки юкә агачы түшәгәннәр, аркылыга тыгыз итеп утын агачлары тезгәннәр, өсләрен куе камыр халәтенәчә чылатылган көл б-н каплаганнар; әзерләнгән көл сыланып беткәнче, утыннарны рәт-рәт итеп өйгәннәр һәм өемне яндырганнар. Учак янып беткәндә шадрик әзер булган. Агачны яндырып ясалган һәм Россиядән чыгарылган поташ сәүдәдә «Казан поташы» исемен йөрткән, ул, башлыча, Казан һәм Оренбург губерналарында җитештерелгән. 20 йөз башында сәнәгать содасы таралыш алу сәбәпле, С.-п.к. бетүгә йөз тота.

*Әд.:* П о п о в Н. Лесная технология. Рук. к механической и химической обработке дерева. СПб., 1871; Х а л и к о в Н.А. Промыслы и ремёсла татар Поволжья и Урала (середина XIX – начало XX в.). К., 1998.

**СЕЛЬДЕРЕ́Й** (Apium), чатырчәчәклеләр семьялыгыннан бер-, ике- яисә күпьеллык үсемлекләр ыругы. Якынча 20 төре билгеле; Европа, Азия, Африка, Америка, Австралиядә таралган. Диңгез һәм елга яр буйларында дымлы туфракларда үсә. Исле С.ның (A. graveolens) — икееллык (сирәгрәк берьеллык) өч төрле төре культуралаштырыла: яфраклы С. (өсәлә торган), саплы С. (салат өчен), тамырчалы С. Вегетация чоры беренче елда 80–150, икенче елда 80–110 көн. Салкынга чыдам: шытымнары — 4°С ка кадәр, зур үсентеләре — 7°С ка кадәр кырауларга чыдам. Беренче елны тармаклы тамырлар яисә тамыразык һәм яфраклары (барлык төрләренең дә төксез, ялтыравыклы), икенче елны — сабаклары (туры, буразналы, тырнаклы, 30–100 *см* биеклектә) һәм вак ак чәчәкле чәчәк оешмасы (катлаулы чатыр) барлыкка килә. Җимеше — ике орлыклы. Орлыклары вак, кабыргалы, озынча, соры яисә коңгырт-көрән; кабыгында тиз әче тәм керә торган эфир майлары күп, шуның нәтиҗәсендә тишелүчәнлеге кими. У н д ы р ы ш л ы



Саплы сельдерей.

туфракларда үсентеләр юлы б-н үстерелә. ТРда тамыразыклы С.ның «Яблочный раннеспелый» сорты (уңышы 1 *га* дан 250–300 *ц*) чәчәргә рөхсәт ителгән. Яфраклары, саплы яфраклары һәм тамырчалары кулинариядә, консервлау сәнәгатендә, орлыкларыннан алынган эфир майлары фармацевтикада кулланыла. С. тонусны күтәрү үзлегенә ия, яфраклары С витаминына бай. Нигездә, бакча, йорт яны участокларында үстерелә.

*Әд.:* Справочник по овощеводству. Л., 1982.

*Р.Ә.Әсретдинова.*

**«СЕ́ЛЬСКОЕ И ЛЕСНО́Е ХОЗЯ́ЙСТВО ТАТАРСТА́НА»** («Татарстанның авыл һәм урман хуҗалыгы»), а.х., икътисад журналы. «*Вестник Казанской областной сельскохозяйственной опытной станции*» ж-лының дәвамчысы. ТАССР Җир эшләре халык комис-ты органы. 1921–24 елларда Казанда рус телендә нәшер ителә, даими чыкмый. 1921–23 тә «Сельское хозяйство Татарстана» исеме б-н чыга. 1922 нең мартыннан 1923 нең мартына кадәр басма кризис һәм халык комис-тының корылык һәм ачлык нәтиҗәләре б-н көрәшүе сәбәпле чыкмый тора. 1922–23 тә редакция кушымта рәвешендә «Сельскохозяйственный листок» г-тасын нәшер итә. Редакция Татарстан Респ-касында а.х.ның «тирән фәнни-техник һәм иҗтимагый-икътисади нигезен эшләү һәм гамәлгә кую»ны максат итә. Төрле елларда мөхәррирләре: проф. А.Н.*Остряков*, ТАССР Җир эшләре халык комиссары Ю.Н.*Вәлидов*, проф. Ф.Т.Дитякин. Журнал б-н профессорлар В.Г.Беляев, В.И.Логинов, В.И.Нечкин, Г.С.Судейкин, галим агрономнар Ф.А.Александров, А.Апанаев, И.В.Благовещенский, М.Ф.Герасимов, Л.И.Колтыпин, Н.Н.Морозов, Л.А.Ташиков, И.И.Штуцер һ.б. хезмәттәшлек итәләр. Журнал а.х. фәне уңышлары, җир эшләренең яңа ысуллары, алдынгы тәҗрибә б-н таныштыра. Редакция саранча б-н көрәштә аэропланнар куллану мөмкинлеге турында язма бастыра; а.х. һәм фәнни белемнәр тарату, крәстиян хуҗалыгын алып баруда коллектив формаларны пропагандалау буенча эш алып бара. ТАССР Җир эшләре халык комис-ты эшчәнлеге даими яктыртыла. Күренекле язмалар арасында В.П.Антоновның «Казан авыл хуҗалыгы фермасы турында кыскача тарихи очерк» («Краткий исторический очерк Казанской сельскохозяйственной фермы, 1846–1922»), «Татарстан авыл хуҗалыгы техникумы тормышыннан» («Из жизни Татарского сельскохозяйственного техникума») бар. Журналны укучы крәстияннәрнең сорауларына җаваплар, файдалы киңәшләр басыла. РКП(б) ҮКның «Ведомство басмасын кыскарту турында» 1924 ел, 26 март карары нигезендә журнал басылудан туктый. ТАССР Җир эшләре халык комис-ты параллель рәвештә татар телендә «Игенче» (к. «*Татарстан авыл хуҗалыгы*») ж-лы чыгара.

*Әд.:* Ф а с а х о в К.М. С жизнью в ногу (Периодическая печать Татарии в восстановительный период). К., 1979.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«СЕЛЬСКОХОЗЯ́ЙСТВЕННЫЙ ЛИСТО́К»** («Авыл хуҗалыгы сәхифәсе»), к. «*Сельское и лесное хозяйство Татарстана*».

**СЕМА́ХИНА** Любовь Анатольевна (12.9.1950, Архангельск ш.), галим агроном, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1978), Киров өлкәсенең «Шурминский» нәсел үрчетү с-зында агроном булып эшли. 1975–79 һәм 1985–96 елларда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының селекция бүлегендә. 1979–85 тә Татарстан респ-ка үсемлекләрне саклау станциясендә агроном. 1996–2006 да «Татплодоовощпром» концернының бакчачылык бүлегендә баш агроном. Салкынга һәм корылыкка чыдам көзге бодайның «*Казан 84*», «*Мишә 2*» (ТР Дәүләт бүләге) һәм язгы бодайның «Керба» сортлары авторларының берсе.

**СЕМБЕ́Р МӨСЕЛМАННАРЫ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, хәйрия оешмасы. 1908 елның 8 декабрендә Сембер шәһәрендә оештырыла. Башлап йөрүчеләре: К.Ш.Абушаев, Х.Х.Ассанович, И.К.Акчурин. Төп максаты — мөселман мәгарифе һәм мәдәнияте үсешенә һәм мохтаҗларга матди ярдәм итү. 1911 елда оешма җирле администрация тарафыннан ябыла. 1915 нең 12 маенда Сембер татарлары яңа хәйрия оешмасы уставын раслауга ирешәләр (башлап йөрүчеләре: Г. һәм Х. Ишуковлар, Г.Гафаров һ.б.). 1917 еллардан соң эшчәнлеге туктала.

*Ж.С.Миңнуллин.*

**СЕМЕ́ННИКОВ** Виталий Семёнович (24.8.1935, Сталинград ш., хәзер Волгоград ш. — 2007, Украина, Запорожье ш.), мәхкәмә табибе, мед. фән. д-ры (1974), проф. (1975). Алтай мед. ин-тын (Барнаул ш.) тәмамлаганнан соң (1960), шунда ук мәхкәмә медицинасы кафедрасында эшли. 1970 елдан Казан мед. ин-тының мәхкәмә медицинасы каф. мөдире, бер үк вакытта, 1974–79 да, дәвалау-профилактика ф-ты деканы. 1980 нән — Калинин, 1984 тән Запорожье мед. ин-тларында дәвалау-профилактика кафедралары мөдире. Хезмәтләре механик буылу нәтиҗәләренә диагноз кую һәм мәхкәмә-мед. экспертизасы ясауга карый. Механик имгәнүләргә экспертиза ясауның суд-мед. критерийларын эшли. Бөтенроссия мәхкәмә табибләре җәмгыятенең Татарстан бүлеге рәисе (1970–80).

Х е з м.: Дифференциальная диагностика основных механизмов травмы костей таза // Вопросы теории и практики судебной медицины. К., 1973 (автордаш); Судебно-медицинские критерии оценки повреждений первого и второго шейных позвонков // Казан. мед. журн. 1980. № 1.

**СЕМЁНОВ** Валерий Васильевич (9.5.1940, Үзбәкстан ССР, Карши ш.), биолог-генетик, мед. фән. д-ры (1994), проф. (1998). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1966), шунда ук биол. кафедрасында эшли, 2001 елдан мед. биологиясе һәм генетика каф. мөдире. Хезмәтләре антимутагеннарны, аларның тәэсиренең рецептор механизмын, канның мутаген һәм антимутаген үзлекләрен өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Рецепторно-регуляторные механизмы действия антимутагенов // Вестн. РАМН. 1997. № 7; Генопротекторная активность крови человека и её механизмы // Рос. физиол. журн. 2002. Т. 88, № 1.

**СЕМЁНОВ** Виссарион Фёдорович (25.9.1932, Иркутск ш. — 22.11.1993, Казан), икътисад фән. д-ры (1975), проф. (1977), ТАССРның һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1982, 1990). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1955), шунда ук эшли, политэкономия каф. мөдире (1968 дән). Икътисад ф-тын оештыручылардан берсе һәм деканы (1992), ун-т каршындагы Идарә һәм бизнес югары мәктәбенең фәнни җитәкчесе. Хезмәтләре милек, җитештерү концентрациясе һәм нәтиҗәлелеге, төбәк икътисады, базар мөнәсәбәтләре шартларында югары мәктәп икътисады мәсьәләләренә карый. Икътисад теориясе нигезләре буенча дәреслек авторларыннан берсе. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Производственный трудовой коллектив. М., 1983 (автордаш); Эффективность производства: Пути и резервы роста. К., 1985; Экономическая самостоятельность и ответственность предприятия. М., 1990 (автордаш).

*Ф.С.Зыятдинов.*

**СЕМЁНОВ** Владимир Фёдорович (16.4.1951, Казан), картограф, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995), техник фән. канд. (1984). Мәскәү Геодезия, аэрофотосъёмка һәм картография инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), ЦНИИгеолнерудта (Казан) эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1995 елдан). 2001 дән Дефектоскопия үзәгенең (Казан) инженерлык эзләнүләре бүлеге башлыгы. Дәүләт бүләге ТРда төзелеш материалларының минер.-чимал базасын бәяләүдә һәм картографияләүдә катнашканы өчен бирелә.

**СЕМЁНОВ** Георгий Виссарионович (7.12.1954, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1993), проф. (1995). 1977 елда Казан ун-ты механика-матем. ф-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, икътисади кибернетика каф. профессоры (1993 тән). 2001 дән 2013 кә кадәр Казан технол. ун-тында менеджмент һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге каф. мөдире, менеджмент һәм маркетинг югары мәктәбе директоры (2010 нан), бер үк вакытта (2010 нан), ТР ФАнең Перспективалы икътисади тикшеренүләр үзәге директоры. Хезмәтләре тигезсез рентага йөз тоткан төбәк икътисади системалары һәм милли продуктның ныклы инновацион үсеше мәсьәләләренә карый. РФ хөкүмәте каршындагы икътисади реформалар эшче үзәгенең Казан вәкиллеге җитәкчесе (1992–94), ТР тышкы икътисади элемтәләр министры киңәшчесе (1995–98). ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Кыйммәтле кәгазьләр һәм фонд базары буенча комиссиянең эксперт советы рәисе (1998–2001).

Х е з м.: Национальный продукт: проблемы дефицита и сбалансированности. К., 1993; Исследование систем управления. К., 2004 (автордаш); Инновационные ресурсы вузов региона: потенциал и организационно-экономические механизмы его использования. К., 2005 (автордаш).

**СЕМЁНОВ** Николай Иванович (12.7.1915, Казан губ., Чистай өязе Чистай Выселкасы а.), Дан орденының тулы кавалеры (13.11.1944, 21.2.1945, 31.5.1945), өлкән сер-


Н.И.Семёнов.


Н.Н.Семёнов.

жант. Суднолар ремонтлау з-дында эшли. 1937–39 елларда һәм 1942 дән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең апреленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, танкка каршы ата торган мылтык взводы отделениесе командиры, 1086 нчы укчы полкның укчы ротасында взвод командиры ярдәмчесе (3 нче армиянең 323 нче укчы дивизиясе). Брянск, Үзәк һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Орёл (1943), Гомель-Речица (1943), Белоруссия (1944) һәм Берлин (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 24 июнендә Друть елгасы буенда Озераны авылы (Гомель өлкәсе Рогачёв р-ны) янында дошман оборонасын өзгәндә батырлык күрсәтә: гаскәр б-н елганы кичеп чыккач, беренчеләрдән булып дошман траншеясына бәреп керә, дошманның ике солдатын юк итә, өчесен әсир ала һәм батальон штабына алып кайта; 1944 нең 17 апрелендә С. җитәкчелегендәге взвод Фюрстенберг шәһәреннән (Германия) төньяктарак беренчеләрдән булып Одер елгасын кичеп, дошман траншеясын ала, пулемёт расчётын сафтан чыгара, С. үзе, траншеяга бәреп кереп, дистәдән артык дошман солдатын юк итә; 1945 нең 14 гыйнварында, Висла елгасы ярында (Юзефув шәһәреннән 15 *км* төньяктарак, Польша) каршы як оборонасын өзү өчен барган бәрелештә дошман тылына үтеп кереп, аның 3 пулемёт ноктасын, 1 автомашинасын юк итә һәм 2 тубын кулга төшерү өчен мөмкинлек ача. 1945 нең 30 апрелендә Бухгольц шәһәренә (Германия) керү юлындагы сугыш барышында: ике сугышчы б-н бергә гранаталар б-н дошман расчётын һәм штурм коралларын сафтан чыгара, контрһөҗүмгә каршы торганда сафтан чыккан командирны алыштырып, автомат уты б-н дошманның күпләгән солдатын һәм офицерын юк итә. 1945 тә демобилизацияләнгәннән соң туган авылында, соңрак Чистай шәһәрендә яши, трикотаж ф-касында мастер ярдәмчесе булып эшли. 1 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СЕМЁНОВ** Николай Николаевич (3.4.1896, Саратов ш. — 25.12.1986, Мәскәү), физик-химик, химия фән. д-ры (1946), СССР ФА академигы (1932; 1929 дан мөхбир әгъза), Соц. Хезмәт Герое (1966, 1976). Химик физикага нигез салучыларның берсе, фәнни мәктәпне нигезләүче. 1917 елда Петроград ун-тын тәмамлаганнан соң, 1918 дән Томск ун-тында эшли. 1920–31 дән Ленинград физика-техника ин-тында (1922 дән электрон күренешләр лаб-ясе мөдире, 1927 дән директор урынбасары, 1927–31 дә химия-физика секторы җитәкчесе), бер үк вакытта, 1920–31 дә, Ленинград политехник ин-тында, проф. (1928). 1931–86 да СССР ФА Химик физика ин-тының директоры һәм 1972 дән чылбырлы процесслар лаб-ясе мөдире (1941–43 тә ин-т Казанга эвакуацияләнә), бер үк вакытта Мәскәү ун-тының химик кинетика (1944–86) һәм Мәскәү инженерлык-физика ин-тының тиз үтүчән процесслар (1951–59) кафедралары мөдире. 1957–63 тә СССР ФАнең Химия фәннәре бүлеге акад.-секретаре, 1963–71 дә вице-президенты. С. чылбырлы реакцияләрнең (тармакланган, тармакланмаган, «тармаклануы бозылган») гомуми микъдари теориясен төзи, аларның химиядә киң таралуын һәм гамәли әһәмиятен күрсәтә (СССР Дәүләт бүләге, 1941). Катлаулы чылбырлы реакцияләрнең химик механизмын ачыклый, чылбырлы процессларның иң гади стадияләре өчен зарури булган ирекле атом һәм радикалларның үзлекләрен өйрәнә (Англия галиме С.Н.Хиншелвуд б-н берлектә; Нобель бүләге, 1956). Бөек Ватан сугышы елларында Казанда С. җитәкчелегендә фронт һәм тыл өчен кирәкле гамәли мәсьәләләр хәл ителә (газларда яну һәм детонация теориясе, «Катюша»лар өчен реактив снаряд дарыларының януы, шартлаучан матдәләрне транспортлау һәм аларның нәтиҗәлелеген күтәрү, шпалларны янудан саклый торган сеңдергечне яхшырту һ.б.). «Химическая физика» ж-лының баш мөхәррире (1981 дән). СССР ЮС депутаты (1960–70). Ленин бүләге (1976), СССР Дәүләт бүләге (1949), СССР МС бүләге (1981), СССР ФАнең Д.И.Менделеев исем. бүләге (1936) лауреаты. Тугыз Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары; медальләр, ш.и. СССР ФАнең М.В.Ломоносов исем. медале б-н бүләкләнә. Европа, Азия, Америкадагы күп илләр академияләренең шәрәфле әгъзасы.

Х е з м.: Цепные реакции. М.–Л., 1934; О некоторых проблемах химической кинетики и реакционной способности. М., 1958; Наука и общество. М., 1973.

*Әд.:* Николай Николаевич Семёнов // Материалы к биобиблиографии учёных СССР. Сер. хим. наук. М., 1966. Вып. 38.

**СЕМЁНОВ** Эдуард Александрович (2.5.1939, Казан), тренер (волейбол), РСФСРның атказ. тренеры (1968). Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1961). 1961–2000 елларда 4 нче һәм 7 нче Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләрендә тренер-укытучы, методист, Казан җыелма командаларында өлкән тренер (яшүсмерләр, өлкәннәр). 1968, 1970, 1972, 1978 дә — РСФСР (хатын-кызлар), 1977 дә СССР (яшүсмерләр — «Дружба-77» соц. илләр Кубогында җиңүче) командаларында тренерлык эшенә чакырыла. 2002–08 дә хатын-кызлар командасы «Казаночка»да (Россия чемпионы 2002; көмеш медаль алучы, 2002, 2003 (1 нче төркем); «Б» югары лигасы чемпионы, 2003–04, 2004–05) өлкән тренер. 2008 дән «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятенең «Хатын-кызлар волейбол клубы» автоном коммерцияле булмаган оешмада тренер-консультант. Шәкертләре арасында — Л.И.*Логинова*.

**СЕМЁНОВКА КО́МПЛЕКСЫ** (археол.). Актай елгасы (Иделнең сул кушылдыгы) бассейнында Спас р-нының Әҗмәр авылы янында урнашкан. 1950 елларда Куйбышев сусаклагычы сулары астында калган Семёновка авылы исеме б-н аталган (хәзерге вакытта — Иделдә Семёновка утравы терр-ясе). С.к. истәлекләрен өйрәнү 1960 еллар башыннан алып барыла (А.Х.Халиков, Е.П.Казаков, П.Н.Старостин һ.б.). С.к. 1 таш гасыр (мезолит) туктаулыгын, бронза гасырга караган 2 туктаулык һәм 1 каберлекне, Ананьино культурасына нисбәтле 1 авыллык һәм 2 каберлекне, 1 Имәнкискә культурасы авыллыгын, Болгар культурасына караган 4 авыллык һәм 4 каберлекне үз эченә ала. Семёновка I авыллыгы терр-ясендә — Идел буе Болгар дәүләтенең иң элгәреге һәм эре сәүдә-һөнәрчелек үзәкләренең берсендә — торак, хуҗалык корылмалары, һөнәрчелек остаханәләре калдыклары табыла. Фаразланганча, авыллыкта пыяла һәм таштан муенсалар эшләү буенча Идел буе терр-ясендәге иң элгәреге һөнәрчелек остаханәсе урнашкан була (10 йөз ахыры — 11 йөз). Авыллык терр-ясендә ш.у. керамика, тимерчелек һәм сөяк эшләнмәләр, кием детальләре һәм төсле металлдан бизәнү әйберләре, башка илләрдән китерелгән эшләнмәләр, сәүдә әйберләре, 10 йөзгә нисбәтле көмеш дирһәмнәрдән торган 2 хәзинә; Алтын Урда чорына караган икенче бер болгар авыллыгында йортлар, хуҗалык корылмалары калдыклары, ураклар, чалгылар, сука детальләре, төрәннәр, пычаклар, балык тоту кирәк-яраклары, керамика, бизәнү әйберләре, 14 йөзгә нисбәтле көмеш һәм бронза тәңкәләр табыла.

*Әд.:* Археологические памятники Татарии в зоне Куйбышевского водохранилища // Из археологии Волго-Камья. К., 1976; Археологическая карта Татарской АССР. Западное Закамье. К., 1986; К а з а к о в Е.П. Булгарское село X–XIII веков низовий Камы. К., 1991.

*Е.П.Казаков.*

**«СЕМЕНОВО́Д»**, Бөгелмә р-нындагы а.х. пр-тиесе. 1920 елда А.Невский монастыре җирләрендә Бөгелмә кантон ком-тының 2 нче «Невский» с-зы буларак оештырыла. 1926 да исеме «Бөгелмә» итеп үзгәртелә, 1932 дә Разумов исем., 1937 дә — «Татарстанның 17 еллыгы» һәм шул ук елда «Бөгелмә» орлыкчылык с-зы итеп үзгәртелә. 1961 дә Бөгелмә тәҗрибә җитештерү хуҗалыгы (шул ук елда Татарстан а.х. тәҗрибә станциясенә бирелә), 1969 дан «Семеновод» (Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты). 1971 дә «Семеновод»тан «Прогресс» с-зы аерылып чыга (Петровка, Сула, Берлек, Коробково авыллары, Сосновка посёлогы). 2004 тә банкротлыкка чыгарылып таркатыла, аның терр-ясе шул үк исемдәге ҖЧҖ составына керә. Совхозга Надеждино, Забугоровка, Зелёная Роща, Яңалиф (үзәк утары) авыллары керә. А.х. җитештерүендә 1991 дә 127 кеше, 2000 дә — 242, 2004 тә — 133 кеше эшли. Төп юнәлешләр: бөртеклеләр, бөртекле-кузаклы, ярма культураларының сортлы элита орлыгын җитеште-




Семёновка комплексы. 1. Семёновка I авыллыгыннан табылган әйберләр; 2. Семёновка V авыллыгыннан табылган әйберләр.

рү, югары продуктлы башмак тана һәм тана сыерлар үстерү. А.х. файдалануы җирләренең мәйданы 6,8 мең *га*, шуларның якынча 6 меңе — сөрүлек җирләр (2003). Хуҗалыкта бөртеклеләрнең еллык уңышы 1 *га* дан 38 *ц* тәшкил итә, ул елына 6–12 мең *т* бөртекле ашлык җитештерә; бөртекле культураларның 2–4 *т* элита орлыгы сатыла, 1 мең башка кадәр башмак тана һәм тана бозаулар үстерелә. Хуҗалык җитештерүдәге югары уңышлары өчен РСФСР МС һәм ВЦСПСның (1976–81, 1986, 1989), КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның (1980) күчмә Кызыл Байрагы һәм дипломнары, СССР ВДНХсы (1977, 1979, 1985, 1987) дипломнары б-н бүләкләнә. Хуҗалыкта эшләүчеләрдән дәүләт бүләкләренә һәм мактаулы исемнәргә, ш.и. ТАССР, ТРның атказ. хезмәткәре исеменә 3 кеше; СССР орден һәм медальләренә 17 кеше лаек була. Хуҗалык үсешенә зур өлеш кертүчеләр: А.И.*Ильин* (1962–84), Н.Р.Бадамшин (1984–96).

*И.Н.Афанасьев.*

**СЕМЕНТО́ВСКИЙ** Владимир Николаевич (1.10.1882, Оренбург губ. Троицк өязе Миасс Заводы пос. — 8.8.1969, Казан), географ-геоморфолог, лимнолог, ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1947). П.И.*Кротов* шәкерте. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1907), Екатеринбург гимназияләрендә укыта. 1908 елдан Казан ун-тында (бүленеп: 1918–26 да Урал, Көнбатыш Себер, Ленинград югары уку йортларында фәнни-пед. эштә), геогр. каф. мөдире (1926–51). Казан ун-тының геогр. ф-тын (1938) оештыручыларның берсе. Хезмәтләре Урал һәм Татарстанның физик географиясенә һәм геоморфологиясенә, лимнология, картография, геогр. укыту методикасына карый. С. экзоген процесслар нәтиҗәсендә барлыкка килгән рельефның морфология һәм морфометриясен анализлау алымнарын эшли. Платформалар рельефының морфологик типларын билгели, аларга морфометрик сыйфатлама бирә, аерым масштаблы геоморфологик карталарның яңа төрләрен күрсәтә. Тау, дала һәм күчеш типларын билгеләп, Урал күлләренең ландшафтлары классификациясен тәкъдим итә. Респ-ка терр-ясен картографияләү буенча эш алып бара, ТАССРның беренче гипсометрик картасын төзи. 40 тан артык фәнни-популяр хезмәтләр авторы, ш.и. «Татарстан табигате: Төбәкне өйрәнү тупланмасы» («Природа Татарии: Краеведческий сборник», 1947), «Татарстан географиясе буенча очерклар» («Очерки по географии Татарии», 1957) китаплары редакторы (Н.И.Воробьёв б-н берлектә). СССР Геогр. җәмгыятенең Татарстан ф-лын оештыручы һәм аның рәисе (1946–62). СССР Геогр. җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы (1959 дан). Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Материалы для геоморфологии и гидрографии территории Большой Казани // Уч. зап. Казан. ун-та. 1940. Т. 100, кн. 3; Из опыта уточнения лимнологических измерений // Уч. зап. Казан. пед. ин-та. 1949. Вып. 8, тетр. 1; Рельеф Татарии. К., 1951 (автордаш); Закономерности морфологии платформенного рельефа (на примере Татарии). К., 1963.

*Әд.:* Д е д к о в А.П., С е м е н т о в с к и й Ю.В. Владимир Николаевич Сементовский. К., 2002.

**СЕМЕНТО́ВСКИЙ** Юрий Владимирович (13.5.1913, С.-Петербург — 15.12.2003, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1973), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1936), Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тында эшли. 1941 елдан Урта Идел геол. идарәсенең (Горький ш.) геол. планга төшерү партиясе башлыгы. 1946 дан ЦНИИгеолнерудта (Казан), директор урынбасары (1967–78), баш фәнни хезмәткәр (1978–2002). Хезмәтләре Татарстанның һәм Россиянең башка төбәкләренең литологиясе, стратиграфиясе һәм руда булмаган файдалы казылмалар геологиясенә карый. С. утырма ятмаларны тикшерү алымнарын һәм аппаратурасын эшли, Головкинский принцибын модификацияли, геол. карта эшләү вакытында терриген материалны күчерү юнәлешен билгеләүнең яңа ысулын кертә, ТР сәнәгый төзелеш материаллары өчен файдалы казылма чыганакларның урынын билгели. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Условия образования месторождений минерального сырья в позднепермскую эпоху на востоке Русской платформы. К., 1973; Нерудные минеральные ресурсы ТАССР: Справ. К., 1982 (автордаш).

*О.Г.Столова.*

**СЕМИОЗЁРКА** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 16 *км* көнбатыштарак, Солонка елгасы буенда. 2010 елда 139 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, китапханә. 1719 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Подмонастырская бистәсе исеме б-н билгеле. Халкы башта Седмиозёрный монастырена карый, 1763 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлек асрау, умартачылык, тимерчелек, он тарту, итек тегү, тире иләү, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында монастырь, земство хастаханәсе, чиркәү-приход мәктәбе (1875 тән эшләүче монастырь җирлегендә 1885 тә ачыла), 2 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 8 вак-төякләр кибете, халыкта аек яшәү рәвеше тәрбияләүче уку өе-китапханә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1242 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кавал волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1728 дә — 28, 1744 тә — 70, 1782 дә — 76 ир-ат; 1859 да — 332, 1897 дә — 542, 1908 дә — 722, 1920 дә — 869, 1926 да — 868, 1938 дә — 665, 1949 да — 547, 1958 дә — 564, 1970 тә — 364, 1989 да — 112, 2002 дә — 151 кеше.

С. тирәсендә *Седмиозёрный Богородица пустыне* биналар комплексы — 19 йөз архит-расы истәлеге саклана.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**СЕМИОЗЁРКА УРМАНЫ́**, ландшафтлы табигать истәлеге. Яшел Үзән р-ны Берновые Ковали авылыннан көньяк-көнбатыштарак

һәм Биектау р-ны Семиозёрка авылыннан төньяктарак урнашкан. Урман массивы Солонка (Солоница) елгасының уңъяк яры буенда (Шәһәр яны урманчылыгының Кызыл Октябрь участок урманчылыгы өлеше). 1986 елда билгеләнә. Мәйданы 118,9 *га*. Текә тау битендәге чыршы, нарат, юкә, каен һәм усактан торучы ылыслы-яфраклы урман участогын били. Яшь агачлардан — ак чыршы, куаклыклардан чикләвек, кабар агачлары, зелпе үсә. Үлән капламында сәрдә, зибык уты,



Семиозёрка урманы.

чәчсыман күрән өстенлек алган. ТРның Кызыл китабына кертелгән сәхләбчәләр вәкилләре һ.б. үсемлекләрнең сирәк төрләре: абага гөл, кызыл серкәбаш, ике яфраклы төнге миләүшә, чын башмакчәчәк, кызыл җиләкле бүре бөресе, гади бүре җиләге, яшел чәчәкле каеш яфрак үсә. ТР фаунасы өчен сирәк төр — гади төн күгәрчене оялый. Җир асты су чыганаклары (ш.и. 2 чишмә — христианнарның изге урыны) бар.

**СЕНА́Ж**, табигый печәнлекләр һәм чәчүлекләрдән (кузаклылар чәчәк ата башлаганчы җыела, кыяклылар — башаклану фазасында) 50–55% дымлылыкка кадәр киптерелгән һәм вакланган терлек азыгы. Кузаклыларны тизрәк киптерү өчен изәләр. С.ны бетон траншеяларга, сенаж башняларына салалар. 2000 еллар башыннан С.ны плёнкага төреп салу киң тарала. С. физиол. коры мохит (бактерияләрнең актив үсешен булдырмау) шартларында консервлана. Бу максатларда биек булмаган сенаж саклагычларда массаны тыгызлыйлар. 16–18 *м* биеклектәге башняларда С. үзеннән үзе тыгызлана. Дөрес әзерләнгән С. таралучан, суыкта катмый торган терлек азыгы. Мөгезле эре терлек рационында силос б-н печәнне тулысынча алыштыра ала. 100 *кг* С.да (клеверлы) якынча 35–40 азык берәмлеге, 4–5 *кг* үзләштерелә торган протеин, 450–460 *г* кальций, 200–220 *г* фосфор, 3000–4000 *мг* каротин бар. С.ны күпләп әзерләү Татарстанда 1960 елларның 2 нче яртысында башлана. 2007 дә ТРда 3384 мең *т* С., ш.и. якынча 100 мең *т* төрелгән С. әзерләнә.

*Әд.:* Технология заготовки и переработки кормов // Система ведения животноводства ТАССР. К., 1983; М а л и к о в М.М. Система кормопроизводства в Республике Татарстан. К., 2002.

**СЕНА́Т ФӘРМАНЫ́** (1720 ел, 1 сент., «О льготе новокрещёным от всяких сборов и податей на 3 года»). Рус булмаган халыкларны, аеруча Урта Идел буе халыкларын христианлаштыру барышын көчәйтү максатыннан кабул ителә. Православиегә күчкән башка дин вәкилләре фәрман нигезендә 3 елга барлык дәүләт салым һәм җыемнарыннан азат ителә. Казан митрополитына яңа чукынганнарны бүләкләү, чиркәүләр төзү һәм аларны тиешенчә җиһазлау өчен ел саен 1000 сум акча бүлеп бирү карала. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында Россиядә ныгып урнашкан православиедәге рус булмаган халыкларга дәүләт ярдәме системасында төп закон актын тәшкил итә, берничә тапкыр нәшер ителә, Россия законнар б-н эш итү практикасында актив файдаланыла.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 6. № 3637.

*Әд.:* Н о г м а н о в А.И. Татары Среднего Поволжья и Приуралья в Российском законодательстве второй половины XVI–XVIII вв. К., 2002.

*А.И.Ногманов.*

**СЕНА́Т ФӘРМАНЫ́** (1742 ел, 19 нояб., «О недопущении в Казанской губернии строить мечети и о разведывании губернаторам и воеводам о обращённых в магометанский закон новокрещёных людей»). Рус булмаган халыкларны христианлаштыру буенча 1740–50 еллар кампаниясе чорының иң әһәмиятле закон актларыннан берсе. Казан губернасында, аеруча яңа чукындырылганнар яши торган җирләрдә, *Патша Фёдор Иванович фәрманы* (1593 ел, 18 июль) чыкканнан соң төзелгән мәчетләрне җимерергә боерыла. Казан, Себер, Әстерхан һәм Воронеж губерналарында яңа мөселман гыйбадәтханәләре төзүне тыя һәм элегрәк салынганнарына теркәү уздыра. Губернаторларга, провинция һәм шәһәр воеводаларына мәҗүсилектән ислам диненә күчү очракларын ачыклау бурычы йөкләтелә, күчүгә булышлык күрсәткән мөселманнарны учакта яндыру юлы б-н җәзаларга кушыла (Губернаторларга 1728 ел боерыгының 19 нчы пункты нигезендә). Ислам динен кабул иткән чуашларны һәм рус булмаган башка халыкларны — чукындыру, каршы булсалар — җәзалау карала. Әлеге фәрманны тормышка ашыру нәтиҗәсе буларак, Казан, Себер һәм Әстерхан губерналарында 1744 елга 545 мәчет юкка чыгарыла.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 11. № 8664.

*Әд.:* Н о г м а н о в А.И. Татары Среднего Поволжья и Приуралья в Российском законодательстве второй половины XVI–XVIII вв. К., 2002.

*А.И.Ногманов.*

**СЕНА́Т ФӘРМАНЫ́** (1744 ел, 8 март, «О поселении Казанских татар в городе Оренбург, и о позволении им построить мечеть вне города»). Фәрман Оренбург губернаторы И.И.Неплюев тәкъдиме б-н кабул ителә. Төбәкнең үзләштерелүен тизләтү һәм сәүдәне үстерү максатыннан, ул төрле яктан, ш.и. Казан губернасыннан да сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләр чакырта. Татарларны күченүгә, икътисади сәбәпләрдән тыш, «Оренбург шәһәренә өстенлекләр»дә («Привилегии городу Оренбургу», 1734 ел, 6 июнь) каралган рекрут бирү йөкләмәсеннән азат ителү һәм дин ирекe бирелү дә җәлеп итә. Сенат Оренбург янында аерым татар бистәсенә нигез салырга һәм анда мәчет төзергә рөхсәт бирә. Җирле халыкның русларны һәм башка милләт вәкилләрен ислам диненә тартмаска тиешлеге шарт итеп куела. Казан татарларыннан нибары 200 гаиләгә генә күченүгә рөхсәт бирелә, алар «хәлле һәм сәүдә алып барырлык, шул сәбәпле анда, ягъни яңа күченгән урында, коммерция эше җәелдерерлек» булырга тиеш дип күрсәтелә. Күченүчеләр өчен, рекрут бирү урынына, зарурлык туганда Оренбург чик сызыгын күчмә кабиләләр һөҗүменнән саклаучы вакытлы гаскәрләрдә хезмәт итү карала. 1744 ел фәрманы татар сәүдәгәрләрегә барлыкка килүдә зур әһәмияткә ия була, Россиянең Көнчыгыш илләре б-н икътисади һәм дипломатия мөнәсәбәтләре үсешенә булышлык итә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 12. № 8893.

*Әд.:* Н о г м а н о в А.И. Татары Среднего Поволжья и Приуралья в Российском законодательстве второй половины XVI–XVIII вв. К., 2002.

*А.И.Ногманов.*

**СЕНА́Т ФӘРМАНЫ́** (1763 ел, 7 авг., «О беспрепятственной торговле Казанских слободских служилых татар, по силе данных им жалованных грамот»). Фәрман чыгарылуга Казанның татар бистәләре халкы б-н Казан магистраты һәм рус сәүдәгәрләре арасында бистә татарларының сәүдә өлкәсендәге өстенлекләре, ягъни юридик яктан сәүдәгәрләр катлавында тормасалар һәм тиешле салымнарны түләмәсәләр дә, 17 йөздән бирле Россия сәүдәгәрләренә каралган хокуклардан файдаланулары мәсьәләсендә туган каршылык сәбәп була. 1762 елның мартында татарларның Гостиный двордагы һәм шәһәрнең башка урыннарындагы 29 кибетен яптыру каршылыкны иң югары ноктага җиткерә. Үз хокукларын яклауда бистә халкы «акчалата һәм икмәкләтә хезмәт хакы» урынына «төрле сату эше» б-н шөгыльләнергә рөхсәт бирелгән һәм аларны земство җыемнары һәм йөкләмәләреннән азат иткән 1686 һәм 1698 еллардагы патша грамоталарына (текстлары 1763 елгы фәрманда китерелә) таяна. Бистә татарларын лашманлык йөкләмәсен үтәгәндә алар буйсынып эшләгән Адмиралтейство коллегиясе дә яклап чыга (к. *Лашманнар*). Каршылык Сенатта каралганнан соң, нәтиҗә буларак, Казанның татар бистәләре халкына бирелгән сәүдә өстенлекләрен раслаган фәрман чыгарыла. Өстенлекләрнең башка урыннарда сәүдә итүче татарларга кагылмавы аерым әйтелә. Казан магистратына «аның алга таба татарларның сәүдә итүләренә каршы төшмәскә тиешлеге» күрсәтелә. 1770 еллардан әлеге фәрманның әһәмияте акрынлап кими бара, чөнки татарлар актив рәвештә сәүдәгәрләр катлавына языла башлый, әмма ул юридик яктан фәкать 1821 дә генә юкка чыгарыла.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 16. № 11888.

*Әд.:* Н о г м а н о в А.И. Татары Среднего Поволжья и Приуралья в Российском законодательстве второй половины XVI–XVIII вв. К., 2002.

*А.И.Ногманов.*

**СЕНА́ТОР РЕВИ́ЗИЯЛӘРЕ**, рев-циягә кадәрге Россиядә Сенатның җирле дәүләт аппараты эшчәнлеген тикшерү формасы. 1722 елның 4 апреленнән император Пётр I Фәрманы б-н кертеләләр. С.р.нең максатлары һәм бурычлары законлаштырылу, сенатор-ревизорларның хокуклары билгеләнү 18 йөз ахырында — 19 йөздә гамәлгә ашырыла. 1799 елның 6 октябреннән император Павел I Фәрманы б-н Россия терр-ясе 8 участокка бүленә (Казан губернасы 7 нче участокка карый), аларның һәрберсе дәүләт учреждениеләрендә гадел хөкем, эчке полиция эшчәнлеге, законсыз рәвештә салым җыю һ.б. мәсьәләләр буенча 2 сенатор тарафыннан даими рәвештә (3 елга 1 мәртәбә) тикшерелә. 1805 ел 1 авг. һәм 1819 ел 17 март «Күрсәтмәләр»ендә каралганча, губерна һәм өяз адм.-полиция, мәхкәмә, хуҗалык һәм финанс учреждениеләре, ә Юстиция министрлыгының император Александр II раслаган 1880 нең 22 сентябрь доклады буенча барлык губерна хакимиятләре, ш.и. мәхкәмә, земство һәм шәһәр учреждениеләре ревизиягә тартыла. С.р.нең нәтиҗәләре хакында сенаторлар император, Сенат һәм Министрлар Кабинеты каршында хисап тоталар.

19 йөздә Казан губернасында 6 С.р. була. **1 нчесе** 1800 елның гыйнвар–февралендә И.В.Лопухин һәм М.Г.Спиридов тарафыннан губерналарның гомуми «Павел ревизиясе» чикләрендә уздырыла. Казан, Козьмодемьянск һәм Чабаксардагы учреждениеләр тикшерелә. Җирле адм. эшчәнлеген тикшерү сенаторларның күрсәтмә пунктлары буенча учреждениеләргә карата таләпләренә һәм икътисад, сәүдә, шәһәр тормышы, халык, дәүләт аппараты торышының төрле тармаклары буенча гомуми мәгълүматлар җиткерүгә кайтып кала. **2 нче** ревизия 1804 нең гыйнвар–июлендә җирле дворяннарның губерна администрациясенең гаеп эшләренә карата шикаятьләре буенча И.Б.Пестель тарафыннан үткәрелә; чиновниклар башбаштаклыгын, хакимият башында торучыларның кыңгыр эшләрен, дәүләт милкен үзләштерүләрен раслаучы фактлар ачыла, бу үз чиратында гражданнар губернаторы Н.И.*Кацаревның* отставкага китүенә һәм күп кенә ришвәтче чиновникларның хөкемгә тартылуына китерә. 1808 нең август–сентябрендә М.И.Донауров тарафыннан үткәрелгән **3 нче** ревизия вакытында Казан, Чабаксар, Зөя һәм Лаештагы кабулханәләр тикшерелә; ревизия үткән учреждениеләрнең күпчелеге сенаторның уңай бәясенә лаек була.

1810 ның гыйнвар–февралендә үткәрелгән **4 нче** ревизиягә Казан, Козьмодемьянскидагы, Тәтеш һәм Чабаксар өязләрендәге кабулханә учреждениеләре дучар ителә. Сенатор П.А.Обрезков чиновникларның халык лашманлык йөкләмәсен үтәгәндә күрсәткән гаепләрен таба, җирле идарә һәм мәхкәмә эшчәнлекләрендәге җитешсезлекләрне билгели.

**5 нче** ревизия 1819 ның октябре — 1820 нең февралендә Казан дворянлыгы, крәстияннәр һәм авыл җәмәгатьләренең хакимиятләрнең кыңгыр эшләренә карата шикаятьләренә бәйле рәвештә С.С.Кушников һәм П.Л.Санти тарафыннан уздырыла. Казан, Чабаксар, Зөядәге кабулханәләр тикшерелә, Казан губернасындагы күп кенә өязләрдә тикшерү үткәрелә. Җирле үзидарәнең барлык бүлекләрендә дә урындагы кешеләрнең башбаштаклыклары һәм җәбер-золымнары фактлары, мәхкәмә эшләрен һәм финанс хисапларын алып баруда тәртипсезлек һәм дәүләт аппараты эшчәнлегендәге башка җитешсезлекләр ачыла. Сенаторларның шелтәләре һәм тәкъдимнәре хакимият органнарының — авыл һәм волость идарәсеннән алып губерна идарәсенең һәм губерна җитәкчесенең эшчәнлегенә кагыла. Ревизия нәтиҗәләреннән соң гражданнар губернаторы И.А.*Толстой* вазифаларыннан азат ителә, 1340 тан артык кеше хөкемгә тартыла. Тикшерү эшләрен карау һәм нәтиҗә чыгару өчен, С.р. тарафыннан башында Д.В.Тенишев торган Казан вакытлы комиссиясе (1820–22), Казан җинаять эшләре буенча мәхкәмә палатасының вакытлы департаменты (1823–27) булдырыла.

1880 нең сентябрендә М.Е.Ковалевский тарафыннан оештырылган **6 нчы** ревизия вакытында Казанның барлык губерна учреждениеләрендә дә тикшерү үткәрелә. Сенатор крәстияннәрнең социаль-икътисади көнкүрешен, халык мәгарифе эшенең торышын, раскольниклар мохитен өйрәнә, салымнар җыюдагы һәм мәхкәмә ин-тлары эшчәнлегендәге җитешсезлекләрне ачыклый, җирле администрациянең башбаштаклыкларына һәм законнарны бозуларына карата халыкның шикаятьләрен тикшерә. С.р. нәтиҗәсендә губернатор Н.Я.*Скарятин* хөкемгә тартыла.

Сенатор-ревизорлар хисапларында губернаның 19 йөздәге икътисади торышы, халыкның социаль хәле һәм губерна тормышының башка яклары турында әһәмиятле мәгълүматлар тупланган.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 6. № 3931; Т. 25. № 19139; Т. 28. № 21861; Т. 36. № 27722; Собр. 2. СПб., 1884. Т. 45, отд. № 1. № 61334; Отд. 2. № 61387.

*Әд.:* Загоскин Н.П. Казанский разгром 1819–1820 гг. // Волжский вестн. 1892. 24, 28 июня; Блинов И.А. Отношение Сената к местным учреждениям в XIX веке. СПб., 1911; шулук. Сенаторские ревизии // История Правительствующего Сената за двести лет. СПб., 1911. Т. 3; Паина Э.С. Сенаторские ревизии и их архивные материалы (XIX — начало XX в.) // Некоторые вопросы изучения исторических документов XIX — начала XX в. Л., 1967.

*Е.Б.Долгов.*

**СЕНА́ТОРОВ** Павел Петрович (12.8.1946, Казан), геолог-икътисадчы, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995), геол.-минерал. фән. канд. (1980), ТРның атказ. геологы (2000). Казан ун-тын тәмамлый (1969). 1971 елдан ЦНИИгеолнерудта (Казан) эшли, икътисад һәм җир асты байлыкларыннан файдалану бүлеге мөдире (2007 дән). 1984–87 дә Вьетнам Соц. Респ-касында командировкада. Дәүләт бүләге ТРда төзелеш материалларының минераллар-җитештерү комплексы проблемаларын геол. һәм икътисади яктан тикшергәне һәм нигезләгәне өчен бирелә. «Дуслык» (Вьетнам Соц. Респ-касы) медале һ.б. б-н бүләкләнә.

Хезм.: Карта состояния и перспектив развития минерально-сырьевой базы промышленности строительных материалов Республики Татарстан. Екатеринбург, 1992 (автордаш); Методическое руководство по поискам, оценке и разведке месторождений твёрдых нерудных полезных ископаемых Республики Татарстан: В 3 ч. К., 1999–2001 (автордаш).

**«СЕ́НЕ ЯЛ»** («Çӗнӗ ял» — Яңа авыл»), крәстиян газетасы. ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты чуаш секциясе органы. 1925 елның 27 гыйнварыннан 1926 га кадәр Казанда чуаш телендә нәшер ителә. Газетаның максаты авылда коммунистлар партиясе йогынтысын көчәйтү, авыл халкын сәяси агарту була. Крәстиян хуҗалыгын алып бару буенча файдалы киңәшләр һәм төрле белешмәләр дә басыла.

**СЕНПО́ЛИЯ**, узамбар миләүшәсе (Saintraulia), геснериячәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 21 төре билгеле. Чыгышы — Көнчыгыш Африканың таулы районнары. Түгәрәк яки аз гына озынча төкчәле яфрак таралгысыннан торучы биек булмаган үсемлек. Чәчәкләре шәмәхә, кызыл, алсу, ак яки зәңгәр төстә, 2–7 шәр булып чәчәк төркеменә җыйналган. Хәзерге вакытта миләүшә чәчәкле С.дән (S. ionantha) килеп чыккан катмарлы яки сырлы таҗ яфракчыклы ак, алсу, кызыл, ике төсле берничә йөз гибрид сорты билгеле. Уңайлы шартлар булганда елына 6–7 ай буена чәчәк ата. Күп кенә сортлары ТРда чәчәк атучы декоратив бүлмә гөле буларак үстерелә. Яфрак сабыннан үрчетәләр. Яктылык ярата, әмма туры кояш нурлары һәм һаваның корылыгы начар тәэсир итә.

**СЕНТИМЕНТАЛИ́ЗМ** (франц. sentiment — хис), 18 йөзнең 2 нче яртысы — 19 йөз башы Европа әдәбиятындагы агым. Бу юнәлеш тарафдарларын, күңеленә дөньяга килгәндә үк иң гүзәл табигый сыйфатлар салынган объект буларак, кеше кызыксындыра. Табигать күренешләренә, кешенең хис-кичерешләренә игътибар арта. С.да тасвирлау объекты — хис-тойгылар; әсәрләргә күпмедер дәрәҗәдә дидактика хас, шәхескә хисси тәрбия биргәндә гаилә хәлиткеч фактор дип таныла, авыл шәһәргә каршы куела, цивилизация кешелексез күренеш дип санала, патриархаль көнкүреш идеаллаштырыла, хат алышу, көндәлек язу популярлаша. Агым исеме Л.Стернның «Франция һәм Италия буйлап хисси сәяхәт» («Сентиментальное путешествие по Франции и Италии», 1768) романы б-н бәйле. Рус әдәбиятында Н.М.Карамзин, М.Н.Муравьёв, И.И.Дмитриев иҗатларында чәчәк ата. Европа һәм рус әдәбиятларында ул романтизм формалашуга йогынты ясый һәм әкренләп мәйданнан китә.

Татар әдәбиятында 20 йөз башында барлыкка килә. Аның сыйфатлары М.Акъегетзадә («Хисаметдин менла»), Ф.Халиди («Рәдде бичара кыз», «Кемгә тиеш?»), Г.Камал («Кызганыч бала»), М.Фәйзи («Кызганыч»), К.Тинчурин («Соңгы сәлам»), Г.Исхакый («Ике гашыйк»), М.Гафури

(«Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек», «Ярлылар, яки Өйдәш хатын»), М.Мозаффария («Кызганыч Миңлеҗамал») әсәрләрендә, поэзиядә Н.Думави, З.Бәшири шигырьләрендә чагылыш таба. С.га хас булган эпистоляр (М.Гафури «Мәхәббәт хатлары», Х.Әбелхан «Хатлар арасында») һәм тәүбә (С.Җәлал «Мин инде аңа үпкәләмим») жанрлары үсеш ала.

20 йөзнең 2 нче яртысы әдәбиятында сентименталь тенденция авыл прозасы (мондый әсәрләрне Ф.Миңнуллин «үткәнне сагыну» дип атый) чикләрендә саклана: татар авылы халыкның зирәклеген, гасырлардан килгән әхлакый кыйммәтләрне, традицияләрне саклаучы урын дип тәкъдим ителә. М.Мәһдиев («Бәхилләшү», «Торналар төшкән җирдә», «Кеше китә — җыры кала»), М.Галиев («Нигез») әсәрләрендә беренче планга тарихи хәтер мәсьәләсе чыга. Рухи торгынлыктан чыгу юлларын эзләүгә игътибарын юнәлткән тәүбә прозасында (Г.Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр», А.Гыйләҗевнең «Урамнар артында яшел болын», А.Расихның «Ике буйдак», «Сынау» әсәрләре) ш.у. С. мотивлары һәм алымнары кулланыла. 20 йөз ахырында С.ның кайбер сыйфатлары Ф.Бәйрәмова әсәрләрендә («Болын», «Битлек», «Кыңгырау», «Су кызы», «Канатсыз акчарлаклар») үсеш ала, аларда махсус сәнгать алымнары б-н (хикәяләүне шәхсиләштерү, «аң агышы», геройларның чиктәш халәтләре — төшләр, саташу) читләшү мотивы ачыла. Хәзерге заманның авторлары кайбер әсәрләрен неосентименталь юнәлешкә бәйлиләр (М.Вәлиевнең «Идел яры», М.Галиевнең «Ерак урман авазы», Ф.Яруллинның «Кыйгак-кыйгак каз кычкыра», Ф.Садриевның «Рәхмәт, әтием», Ф.Бәйрәмованың «Кем?» әсәрләре). Бүгенге татар прозасында сентименталь повесть поэтикасы аңа хас лиризм, эчкерсезлек, хисчән геройны күрсәтү б-н генә түгел, язучының Шәрекъ әдәбияты традицияләренә мөрәҗәгать итүе б-н дә билгеләнә.

*Әд.:* Гайнуллин М. Татарская литература и публицистика начала XX века. К., 1966; Миңнуллин Ф. Затлылык. К., 1989; Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. К., 2007.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**СЕНТЮКО́В** Николай Петрович (15.12.1923, Бөгелмә кантоны Яңа Казанка пос. — 13.10.1943, Украина ССР, Днепропетровск өлкәсенең Верхнеднепропетровск р-ны Днепровокаменка авылыннан 4 *км* көньяк-көнбатыштарак җирләнә), Сов. Союзы Герое (20.12.1943, үлгәннән соң), гв. лейтенанты. Куйбышев хәрби һава десанты уч-щесен (1941), Төньяк-Көнбатыш фронтның берләштерелгән офицерлар курсларын (1943) тәмамлый. Туган посёлогында тракторчы булып эшли. 1941 елдан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 19 нчы гв. һава десанты полкында рота командиры (37 нче армиянең 10 нчы гв. һава десанты дивизиясе). Дала фронты гаскәрләре составында Днепр елгасы өчен сугышта (1943), Украинаны азат итүдә (1943) катнаша. Антоновка авылы янындагы (Верхнеднепропетровск р-ны) сугышта батырлык күрсәтә: 1943 нең 13 декабрендә сугыш барышында дошманның 2 танкын сафтан чыгара. Алдагы сугышта дошманның контрһөҗүмен кире кайтарганда тагын 1 танкны юк итеп, һәлак була. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Бөгелмә шәһәрендә С. исеме мәктәпкә бирелә, Геройлар аллеясында С.ның бюсты куела.



Н.П.Сентюков.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СЕНТЯБРЁВ** Николай Иванович (11.12.1909, Иваново-Вознесенск ш. — 30.1.1975, Казан), спортчы, тренер (футбол), СССРның спорт остасы (1946), РСФСРның атказ. тренеры (1962). Иваново машина төзелеше техникумын (1933), Мәскәү физкультура ин-ты каршындагы футбол тренерлары мәктәбен (1952) тәмамлый. 1946 елга кадәр «Динамо» осталар футбол командасы һәм Иваново җыелма командасы уенчысы, СССРның иң яхшы футболчылары исәбенә керә. 1952–54 тә Ковров шәһәренең спорт осталары футбол командасында тренер. 1954–58 дә — «Красное знамя» (Иваново ш.), 1959–71 дә «Искра» (1965 тән — «Рубин», Казан) футбол командаларында өлкән тренер. С. җитәкчелегендә «Рубин» футбол командасы РСФСР беренчелегендә көмеш медаль ала («Б» классы) һәм «А» классының 2 нче лигасына чыга (1965); автономияле республикалар Кубогын яулый (1970). Шәкертләре арасында — СССРның 14 спорт остасы, СССРның олимпия һәм җыелма командалары әгъзалары — В.Булавин, И.Галимов, В.М.*Колотов*, Н.В.Осянин. 1992 дән Казанда ел саен С. истәлегенә Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләре командалары арасында футбол буенча Бөтенроссия турниры уздырыла, 1992 дә Казанда «Рубин» стадионында мемориаль такта куела.

**СЕНЮ́ТКИН** Сергей Борисович (4.12.1951, Горький ш., хәзер Түбән Новгород ш. — 9.8.2004, шунда ук), тарихчы, тарих фән. д-ры (2002), проф. (2004). Горький ун-тын тәмамлый (1974), шунда ук пед. кафедрасында эшли, 1988 елдан яңа һәм иң яңа тарих каф. доценты, 2004 тән чит илләр тарихы каф. профессоры. Хезмәтләре Түбән Новгород мишәр татарлар һәм шул төбәктәге татар авыллары тарихына карый. С. хезмәтләрендә татарларның матди-хуҗалык һәм рухи-дини тормышы мәсьәләләре чагыла, Россиянең эчке тормышы һәм тышкы эшләре вакыйгаларында Арзамас, Алатырь, Кормыш өязләре йомышлы татарларының роле өйрәнелә, Россия татарлары тарихында Түбән Новгород мишәрләренең тарихи үсеш үзенчәлекләре ачыклана. «Түбән Новгород өлкәсе ислам җәмгыятьләре тарихы» («История исламских общин Нижегородской области», Түбән Новгрод, 1998; автордаш) китабы өчен Түбән Новгород бүләге бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә. 2004 тән Түбән Новгород ун-тында ел саен С. истәлегенә багышланган конференцияләр уза.

Хезм.: История татарских селений Большое и Малое Рыбушкино Нижегородской области в XVI–XX веках. Н.Новгород, 2001 (автордаш); История татар Нижегородского Поволжья с последней трети XVI до начала XX вв. (Историческая судьба мишарей Нижегородского края). Н.Новгород, 2009.

*Әд.:* Историки России XX века: Биобиблиогр. словарь. Саратов, 2005. Т. 2; Историческая наука в Нижегородском государственном университете им. Н.И.Лобачевского (1946–2006). Н.Новгород, 2006.

**СЕНЮ́ТКИНА** Ольга Николаевна (5.2.1951, Горький ш., хәзер Түбән Новгород ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2008). Горький ун-тын тәмамлагач (1973), мәктәптә тарих һәм җәмгыять белеме укыта (Горький). 1983 елдан Горький чит телләр пед. ин-тының (хәзерге Түбән Новгород лингвистика ун-ты) КПСС тарихы кафедрасында, 2007 дән культурология, тарих һәм борынгы телләр каф. профессоры. Хезмәтләре Түбән Новгород мишәрләре, татар авыллары тарихына, сәяси төркичелек мәсьәләләренә карый. С. хезмәтләрендә Россиядә төрки хәрәкәтнең беренче партия структуралары оешу шартлары һәм торышы тикшерелә, төркичеләрнең эшчәнлек алымнарына һәм формаларына, аларның киңәшмәләр уздыру үзенчәлекләренә характеристика, Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары барышына һәм карарларына анализ бирелә. «Туган якны өйрәнү» номинациясендә Түбән Новгород бүләге (1998), фән һәм мәгариф өлкәсендә Х.Фәезханов исем. бүләк лауреаты (2006). Россия Мөфтиләр шурасының 2 нче дәрәҗә әл-Фәхр ордены б-н бүләкләнә.

Хезм.: Первый съезд мусульман России. Н.Новгород, 2005; Тюркизм как историческое явление. Н.Новгород, 2007; История Татарской Медяны (XVII–XXI вв.). Н.Новгород, 2008.

*Әд.:* Видные учёные России (Нижний Новгород). Н.Новгород, 2009. Вып. 3.

**«СЕР ЕСЛЕКЕ́Н»** («Çĕр ĕçлекен» — «Игенче»), крәстияннәр журналы. РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-тының Үзәк чуаш бүлеге органы. 1919–20 елларда Казанда чуаш телендә нәшер ителә, барысы 7 саны чыга. Мөхәррире — А.Т.Быков. Төбәктә игенчелек, терлекчелек, бакчачылык, умартачылыкны үстерү мәсьәләләре яктыртыла. Агроном, зоотехникларның кырларның уңдырышлылыгын арттыру, а.х. культураларының яңа сортлары, терлекчелекнең продукция бирүчәнлеге турындагы язмалары чыга. Соңгы битләрендә «Крәстияннәр өчен календарь» сәхифәсе урнаштырыла. Анда йорт хайваннарын карау, бакчада эшләү һ.б. буенча тәфсилле киңәшләр бирелә.

**СЕРГА́Ч РАЙОНЫ́**, *Түбән Новгород өлкәсенең* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1929 елда оештырыла. Мәйданы — 12434 *км*$^2$. Үзәге — Сергач шәһәре (Түбән Новгородтан 237 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 29716 кеше (2013), татарлар — 3122 (2010) кеше. Татарлар, тупланып, 7 торак пунктта: Анды (2008 дә 360 кеше), Мөтеравыл (Андреевка) (400), Грибан (300), Камка (500), Кучкай Пожары (840), Печә (Пица) (300), Шөбиле (Шубино) (570) авылларында яшиләр. Тари-

хи чыганакларда бу авыллар беренче тапкыр 1603–21 елларда искә алына. 1794 тә Түбән Новгород наместниклыгының Сергач округы терр-ясендә «төрле дәрәҗәле» (ш.и. 128 яңа чукындырылганнар) 5251 татар яшәгән 20 торак пункт, 20 мәчет исәпләнә. Халык, нигездә, игенчелек, вак-төякләр сату б-н шөгыльләнә, читкә китеп эшли; аеруча аю үрчетү киң җәелә (Шөбиле, Грибан, Печә, Мөтеравыл, Камка һ.б. авылларда); 1860 елларда бу тыела. 19 йөз ахырында Түбән Новгород губернасының Сергач өязендә 26350 татар була. 1925 тә монда 100 меңнән артык кешесе булган 35 татар торак пункты исәпләнә. 1928 дә өяздә 115 мәчет эшли. 1962–63 елларда С.р.нда — «Колхоз правдасы», 1963–64 тә «Ленин байрагы» татар г-талары нәшер ителә. 1990 нан «Туган як» г-тасы чыга. Районда 12 мәчет эшли (Мөтеравыл, Анды, Камка авылларында — 2 шәр). Татар торак пунктларындагы барлык мәктәпләрдә татар теле фән буларак өйрәнелә. Спутник антенналары аша «Татарстан–Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе тапшырулары кабул ителә. Ел саен *Сабан туе* үткәрелә. Рәссам Л.Г.*Фәттахов* (Анды), язучы З.Р.*Фәтхуллин* (Мөтеравыл), тарихчы Г.Б.*Билалов* (Печә), хирург З.Җ.*Алимов*, техн. фән. д-ры Р.Җ.*Алимов* (Грибан), классик көрәш буенча 1952 елгы Олимпия уеннары чемпионы Ш.С.*Сафин* (Кучкай Пожары), эшкуар һәм меценат Р.Җ.Баязитов (Камка) һ.б. С.р.нда туган.

*Әд.:* Баязитов Р.Ж., Макарихин В.П. Нижегородские татары — мишари в новое время. Н.Новгород, 1996; Хафизов М.З. Нижегородские татары: Очерки истории. Н.Новгород, 1997; Орлов А.М. Нижегородские татары: Этнические корни и исторические судьбы (очерки). Н.Новгород, 2001; Нижегородские татары: Биогр. словарь. Н.Новгород, 2008. Т. 1.

*Х.Ә.Габделкаюмов.*

**СЕРГЕ́ЕВ** Александр Терентьевич (1915, июль, Казан губ., Лаеш өязе Емельяново а. — 3.11.1974, Казан), Сов. Союзы Герое (10.4.1945), өлкән сержант. Туган авылында колхозда, соңыннан Яшел Үзән шәһәрендә агач эшкәртү з-дында, 1938 елдан Казанда В.В.Куйбышев исем. кинотасма ф-касында эшли. 1939 дан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1 нче Украина фронты составындагы 15 нче аерым моторлаштырылган понтон-күпер батальонында сапёрлар отделениесе командиры (6 нчы понтон-күпер бригадасы). Штейнау шәһәре (хәзерге Сьцинава ш., Польша) янында Одер елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: 1945 нең 29 гыйнварында сугыш техникасын һәм хәрби йөкләрне елганың икенче ярына чыгаруда катнаша; 30 гыйнварда С. расчёты тиз арада күпер сала (беренче тәүлектә үк күпердән елга аша берничә частьнe техникасы б-н үткәреп, һөҗүм операциясе өчен плацдарм яуларга, порт һәм шәһәрне алырга мөмкинлек тудыра). Сугыштан соң демобилизацияләнә. Казанда заводта слесарь-җыючы булып эшли. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Емельяново авылында С.ка һәйкәл куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*


А. Тимофеевич Сергеев.


А. Терентьевич Сергеев.


М.Е. Сергеев.

**СЕРГЕ́ЕВ** Александр Тимофеевич (30.8. 1916, Казан губ., Мамадыш өязе Шиланка а. — 10.7.1979, Мәскәү өлкәсе Подольск ш.), Сов. Союзы Герое (31.5.1945), гв. капитаны. Чистай вет. техникумын (1935), Новочеркасск кавалерия уч-щесен (1944) тәмамлый. Туган авылында терлекчелек с-зында эшли. 1937 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 9 нчы гв. кавалерия полкында эскадрон командиры (2 нче гв. кавалерия корпусының 3 нче гв. кавалерия дивизиясе). 1 нче Белоруссия фронты гаскәрләре составында Белоруссия, Люблин-Брест (икесе дә — 1944), Варшава-Познань һәм Берлин (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Фюрстенвальд шәһәре (Берлиннан көньяктарак) өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә. 1945 нең 23 апрелендә аның эскадроны, Шпрее елгасын һәм Шпрее каналын кичеп чыгып, плацдарм яулап ала, дивизиянең калган подразделениеләренә Франкфурт-Одер–Берлин автострадасына чыгуны тәэмин итә, дошманның 8 контрһөҗүмен кире кайтара, 5 корал һәм сугыш кирәк-яраклары складын кулга төшерә. С. сугыштан соң армиядә хезмәтен дәвам итә. 1946 дан запаста. Подольск шәһәрендә яши, урта мәктәптә хәрби әзерлек дәресләре укыта. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СЕРГЕ́ЕВ** Василий Петрович (1.1.1922, Чуаш автономияле өлкәсенең Булдеево а. — 11.7.1989, Казан), дерматовенеролог, мед. фән. д-ры (1974), проф. (1974), Чуаш АССРның атказ. табибе (1960). Проф. Г.Г.Кондратьев шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), Минзәлә район хастаханәсендә эшли. 1952 елдан Чуаш респ-ка тире-венерология диспансеры баш табибе, бер үк вакытта, 1952–54 тә, Чуаш АССР сәламәтлек саклау министры урынбасары. 1965 тән Казан мед. ин-тының тире һәм венерик авырулар кафедрасында. 1970 тән Казан ГИДУВының дерматовенерология каф. мөдире, 1972–75 тә терапия ф-ты деканы. Хезмәтләре хроник дерматоз б-н авыручыларның иммунологик һәм аллергик реактивлыгы мәсьәләләренә карый. Аллопеция (чәч коелу) б-н авыручыларны дәвалауда кулланылган «Силокаст» препаратын эшли; 1867 дә А.М.Зайцев тарафыннан синтезланган димексидның дәвалау үзлекләрен беренче булып өйрәнүчеләрдән (1976). Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Гонорейно-трихомонадное заболевание мочеполовых органов у мужчин. К., 1980; Уретроскопия в диагностике и лечении гонорейных и негонорейных заболеваний мочеполовых органов. Л., 1985 (автордаш); Вопросы патогенеза и терапии псориаза. Л., 1988 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Василий Петрович Сергеев // Казан. мед. журн. 1982. № 1.

**СЕРГЕ́ЕВ** Михаил Егорович (28.1.1924, Лаеш кантоны Югары Тегермәнлек а.), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), гв. лейтенанты. Харьков янгын сүндерү-техник уч-щесен тәмамлый (1955). 1944 елның апреленнән Кызыл Армия сафларында. 1944 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 44 нче мотоукчы бригаданың 3 нче мотоукчы батальонында туп коручы (2 нче гв. армиянең 1 нче танк корпусы). 1 нче Балтыйк буе һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Шауляй, Мемель (икесе дә — 1944) һәм Көнчыгыш Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Шауляй шәһәреннән (Литва) көнбатыштарак барган сугышларда батырлык күрсәтә: 1944 нең 18–19 августында дошманның контрһөҗүмен кире кайтарганда үзенең расчёты б-н 8 танкны юк итә. Тубы сафтан чыккач, мылтык һәм гранаталар б-н сугышуын дәвам итеп, позициясен дошманга бирми. 1946 да демобилизацияләнә. Пыра посёлогында торф пр-тиесендә нормировщик булып эшли. 1964 тән Нефтекумск (Ставрополь крае) шәһәрендә яши, куркынычсызлык техникасы өлкән инженеры, газ эшкәртү з-дында коткару отряды командиры булып эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

**СЕРГЕ́ЕВ** Михаил Павлович (12.1.1949, Алексеев р-ны Красный Барак а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2000), проф. (2002), ТРның атказ. икътисадчысы (1993). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1975), Биектау р-ны Усад авылындагы 2 нче һөнәр уч-щесендә директор урынбасары булып эшли. 1976 елдан Казан а.х. ин-тында, а.х. җитештерүен оештыру каф. мөдире (1989–94). 2000–06 да Татар-Америка төбәк ин-тында: проректор, менеджмент каф. профессоры (2001 дән). 2006–12 дә Татар гуманитар-пед. ун-тында каф. мөдире. 2012–15 тә «ТИСБИ» идарә ун-тында, бер үк вакытта, 2013 тән, Казан технология ун-тында менеджмент һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге каф. профессоры, 2014 тән Агробизнес кадрларының белемен күтәрү ин-тында. Фәнни тикшеренүләре индустриаль типтагы а.х. пр-тиеләренең хезмәт коллективларын формалаштыру һәм алар б-н идарә итү, ш.у. а.х. пр-тиеләре коллективларының социаль-икътисади потенци-

алын файдалану, АПКны кризистан чыгару, икътисади мөнәсәбәтләр һәм идарә итүне камилләштерүгә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Разработка и внедрение новых форм хозяйствования в АПК. К., 1996 (автордаш); Социально-экономический потенциал сельскохозяйственных производственных коллективов. К., 2001; Результаты реформирования сельхозпредприятий. К., 2003; Человеческий капитал и экономическая безопасность России: проблемы и перспективы. К., 2008 (автордаш).

*Ф.С.Зыятдинов.*

**СЕРГЕ́ЕВ** Пётр Сергеевич (1797, Смоленск губ. — 29.5.1868), хокук белгече, статский советник (1838). Дворяннар нәселеннән. Баш пед. ин-тын (С.-Петербург, 1819) тәмамлый. 1821–23 елларда Петербург ун-ты каршындагы Петербург губерна гимназиясендә һәм Затлы нәселләр пансионында өлкән укытучы. 1823–45 тә Казан ун-тында: хокук (1837 гә кадәр), дәүләт төзеклеге һәм әхлагы законнары (1837 дән) кафедралары экстраординар профессоры (1824 кә кадәр), 1824 тән ординар проф., бер үк вакытта, 1823–25 тә, китапханәче, 1829–37 дә әхлакый-сәяси бүлек деканы, 1837 дән юридик ф-т деканы. Тарихи хокук мәктәбе карашларын яклый. Казан уку-укыту округы попечителе М.Л.Магницкий тарафдары. 1823 тә «Университетта юридик фәннәр укыту конспектлары»н («Конспект университетских юридических преподаваний») тәкъдим итә, бирәдә ул Рим хокукын дини һәм дөньяви хокук дуализмы хас Византия хокукы б-н алыштырырга омтыла. 1830 елларда ун-тта мәгариф реформасы б-н бәйле эш алып бара (фәндәге әхлакый-сәяси бүлекләрне юридик бүлекләр б-н алыштыра). Россия почтасы тарихы буенча хезмәтләр, «Философия укыту буенча конспект» («Конспект философских преподаваний», 1827) авторы.

Х е з м.: Исторический взгляд на почтовое управление в России. К., 1840.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–2004). К., 1904. Ч. 2; Е м е л ь я н о в а И.А. Юридический факультет Казанского государственного университета. 1805–1917 год: Очерки, К., 1998.

*Е.Б.Долгов.*

**СЕРГЕ́ЕВКА** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 15 *км* көнбатыштарак, Киса елгасы буенда. 2010 елда 17 кеше (руслар) яши. 1830 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рус Сугышлысы, Кислинка исемнәре б-н дә билгеле. 1940 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 527 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Кузайкино волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 344, 1889 да — 212, 1910 да — 240, 1920 дә — 242, 1926 да — 239, 1938 дә — 251, 1949 да — 217, 1958 дә — 249, 1970 тә — 300, 1979 да — 219, 1989 да — 12, 2002 дә — 7 кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**СЕРГЕ́ЕВСКИЙ** посёлогы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 24 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 83 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1924 тә нигез салына. Оештырылган көненнән Казан губернасының Чистай өязе Котыш волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 167, 1949 да — 111, 1970 тә — 91, 1979 да — 28, 1989 да — 113, 2002 дә — 101 кеше.

**СЕ́РГИЕВ** Пётр Григорьевич (11.7.1893, Вятка губ., Яранск өязе Сретенское а. — 12.7.1973, Мәскәү), паразитолог, эпидемиолог, СССР МФА академигы (1944) һәм вице-президенты (1957–60), СССР сәламәтлек саклау өлкәсе оештыручысы, Соц. Хезмәт Герое (1963). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый (1918). 1927 елдан Мәскәү Тропиклар ин-тында (хәзер Мед. паразитологиясе һәм тропик мед. ин-ты), 1934–69 да — директор. 1969 дан фәнни консультант. Бер үк вакытта, 1937 дә, РСФСР сәламәтлек саклау халык комиссары, 1938 дән РСФСР Сәламәтлек саклау министрлыгының Эпидемияләргә каршы көрәш идарәсе башлыгы. Эшчәнлегенең төп юнәлеше һәм фәнни хезмәтләре бизгәк авыруын (малярия) өйрәнү һәм аңа каршы көрәш оештыруга карый. С. җитәкчелегендә бизгәк авыруы б-н көрәшнең бишьеллык дәүләт планы төзелә (СССР ХКС тарафыннан 1934 тә раслана), әлеге планның үтәлеше бизгәк авыруының массакүләм таралышын туктата. «Медицинская паразитология и паразитарные болезни» ж-лы баш мөхәррире (1934 тән). Венгрия Халык Респ-касы ФАнең (1960), Бельгия тропиклар медицинасы җәмгыятенең (1962) шәрәфле әгъзасы. Дәүләт бүләкләре (1946, 1952), Халыкара Дарлинг исем. бүләк (1965) лауреаты. Өч Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Малярия и борьба с ней в СССР. М., 1956 (автордаш).

*Әд.:* Видные учёные отечественной медицины и здравоохранения — питомцы Казанского медицинского института. К., 1969.

*И.Г.Кадошникова.*

**СЕРГИЕ́ВСКИЙ** Константин Александрович (18.11.1914, Пенза губ. Городище ш. — 29.9.1994, Казан), инженер-механик, Казан төгәл машиналар төзү з-ды директоры (1957–74), Соц. Хезмәт Герое (1971). Хезмәт эшчәнлеген 1932 елда М.В.Фрунзе исем. Пенза машиналар төзү з-дында өлгече-токарь буларак башлый. Ленинград механика ин-тын тәмамлаганнан соң (1940), М.И.Калинин исем. Ленинград машиналар төзү з-дына җибәрелә. 1941 нең октябрендә завод б-н бергә Казанга эвакуацияләнә; өлкән мастер, цех башлыгы урынбасары, җыю цехы башлыгы (1946 дан), баш инженер (1953–57) булып эшли. 1950–53 тә партия эшендә. 1941 дә җыю цехындагы өлкән мастер С. участогы башлап эшкә керешә. Аның җитәкчелегендә пр-тиедә нигездән реконструкция уздырыла, яңа производстволар



К.А.Сергиевский.

оештырыла, җиһазлар яңартыла, катлаулы радиоэлектроника һәм оптика эшләнмәләре җитештерелә башлый. Герой исеме төгәл машиналар төзү үсешенә керткән зур өлеше өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**СЕРГИЕ́ВСКИЙ** Михаил Васильевич (27.10.1898, Сембер губ. Жаренки а. — 1982), физиолог, мед. фән. д-ры (1935), СССР МФАнең мөхбир әгъзасы (1952), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1960). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1926), шунда ук, нормаль физиол. кафедрасында, проф. Н.А.*Миславский* карамагында калдырыла. 1936–77 елларда Куйбышев мед. ин-тының нормаль физиол. каф. мөдире, бер үк вакытта Куйбышев пед. ин-тының физиол. һәм психол. каф. мөдире, 1941–45 тә Куйбышев аптека идарәсендә ашказаны согы әзерләп чыгару лаб-ясе мөдире, 1944–45 тә Хәрби-мед. академиясенең (Куйбышев ш.) физиол. каф. мөдире. Хезмәтләре кан әйләнешен, сулыш алуны көйләүне, сулыш алу һәм йөрәк-кан тамырлары үзәкләренең бер-берсенә тәэсирен өйрәнүгә, мәни бизе (простата) һәм селәгәй бизе физиологиясенә карый. «Сулыш алуны көйләү» («Регуляция дыхания») хезмәте И.П.Павлов исем. бүләккә (1948), «Имезүче хайваннарның сулыш алу үзәге һәм аның эшчәнлеген көйләү» («Дыхательный центр млекопитающих животных и регуляция его деятельности») хезмәте СССР Дәүләт бүләгенә (1952) лаек була. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Периферические или местные рефлексы. М., 1964.

**СЕ́РГИЙ** (Королёв Аркадий Дмитриевич) (18.1.1881, Мәскәү — 18.12.1952, Казан), дин эшлеклесе. Мәскәү руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1906), Яблочно монастыренда (Брест ш. янында), 1907 елдан монахлыкта, 1914 тән архимандрит һәм монастырь башлыгы. 1920 дән Бельск епискобы (Польшада). 1922 дә Польша хөкүмәте тарафыннан илдән сөрелә. 1922 дән Прага епискобы, Чехословакия, Австрия һәм Венгрия викарие. Прагада С. рус эмигрантлары арасында зур абруй казана, мохтаҗларга, авыруларга ярдәм итә. 1939–45 тә немец-фашистлар окупациясе вакытында концлагерьлардан качкан әсирләрне яшерә. 1946 ның июненнән Вена епискобы, Көнбатыш Европа экзархаты викарие. 1946 ның октябреннән Урта Европа экзархаты экзархы. 1948 дән — Берлин һәм Германия, 1950 дән Казан һәм Зөя архиепискобы.

Х е з м.: Казанская икона Божией Матери // Журн. Моск. патриархии. 1952. № 7; Духовная жизнь в миру. М., 2003.

*Әд.:* Журавский А.В. Свидетельства святости: Памяти архиепископа Сергия Казанского и Чистопольского, бывшего Пражского // Рус. Возрождение. 1997. № 2–3; Липаков Е.В. Архипастыри Казанские. 1555–2007. К., 2007.

**«СЕРГО́ ИСЕМЕНДӘГЕ́ ЗАВО́Д»** (ПОЗИС), Яшел Үзән шәһәрендәге оборона сәнәгате җитештерү берләшмәсе. Эшләүчеләр саны — 4,2 мең кеше (2014). Җитештерү мәйданы 2372 мең *м*². 1898 елда Идел-Вишера тау һәм металлургия АҖ француз сәнәгатьчеләре тарафыннан «Паратск корыч коючу заводы» буларак нигезләнә. 1900 дәге икътисади кризис аркасында инде төзелеп беткән бакыр эретү, тимерчелек цехлары, мартен мичләре комплексы, корыч прокаты производствосы һәм электр станциясе файдалануга тапшырылмый. 1917 дә, миналар һәм яктырткыч ракеталар җитештерү нияте б-н, завод корпусларын француз сәнәгатьчесе Н.Бенуа сатып ала. 1917 нең сентябрендә пр-тие куәтләре аның милкеннән Идел-Ижора з-дының (Петроград губернасы Колпино шәһәреннән эвакуацияләнгән Ижора з-ды гильза производствосы җирлегендә оештырыла) карамагына күчерелә, 1919 да — Паратск металлургия з-ды, 1922 дә Арча кантонындагы металл һәм агач эшкәртү пр-тиеләрен берләштергән Паратск сәнәгать комб-ты составына кертелә. Чимал һәм финанс чаралары булмаганлыктан, гильзалар җитештерелми. 1926 да гильза һ.б. металл эшкәртү производстволары консервацияләнә. 1930 ның октябрендә ВКП(б) ҮК аларны мөстәкыйль з-д буларак сафка бастыру турында карар кабул итә. 1931 дә заводка Серго (Г.К.Орджоникидзе) исеме бирелә. Капиталь реконструкция барышында ук (1930–35) инглиз «Гочкисс» һәм «Виккерс» системаларындагы 20–45 *мм* лы җиз артиллерия снарядларын, соңрак эрерәк калибрлы совет үрнәкләре снарядларын эшләү җайга салына. Бөек Ватан сугышы елларында утлы корал өчен патроннар җитештерү үзләштерелә. 1950–80 елларда яңа цехлар төзелә. Оборона продукциясе чыгару б-н бергә халык хуҗалыгында кулланылучы продукция — 1940 еллар ахырыннан а.х. машиналары (чәчкечләр, культиваторлар, сортларга аеру җайланмалары), 1950 еллар башыннан кыру станоклары, тешле кисү автоматлары, сөт бидоннары җитештерү үсеш ала. 1950 еллар ахырында башта «С.и.з.»ны, аннары респ-каның башка пр-тиеләрен (мед. инструментлары, «Сантехприбор», штепсельле аергычлар з-длары) җиһазлау өчен автомат ротор линияләрен һәм механикалаштыру чараларын проектлау һәм эшләп чыгару оештырыла. 1959 да заводта «Мир», соңрак «Свияга» суыткычларын күпләп чыгару җайга салына. Пр-тие СССРда иң эре көнкүреш суыткычлары җитештерүчеләрнең берсенә әверелә, аларны еллык җитештерү 1960 та — 3,7, 1979 да — 179, 1980 дә — 350, 1990 да 414 мең данә тәшкил итә. Завод бернничә тапкыр исемен алыштыра: 1941 дән — 184 нче з-д, 1950 дән — 1 нче п/я оешмасы, 1967 дән «Серго исемендәге завод» дип атала. 1977 дә аның җирлегендә ҖБ, 2000 дә федераль унитар пр-тие төзелә, 2011 дән «Серго исемендәге завод» ҖБ» АҖ. Пр-тиенең оборона продукциясе — кече калибрлы сугыш кирәк-яраклары (патроннар, гранаталар һ.б.), Россиядә җитештерелгән барлык хәрби самолётларда кулланылучы катапульта системалары өчен пиротехник зарядлар (БДБдә бердәнбер пр-тие). Суыткыч техника: 30 дан артык модельдә бер һәм ике камералы көнкүреш суыткычлары һәм туңдыргычлары, сәүдә, җәмәгать туклануы пр-тиеләре, кунакханәләр һәм офислар өчен суыткыч җиһазлар, мед. суыткыч җиһазлары эшләп чыгарыла. Пр-тиедә, «ГАЗ», «ЗИЛ», «КАМАЗ» йөк автомобильләре һәм «СЗАП», «МАЗ» ярымтагылмалары шассилары җирлегендә изотермик автофургоннар һәм авторефрижераторлар җитештерелә. Пр-тиенең төп продукциясенә ш.у. ау һәм спорт мылтыклары өчен 12, 16, 20 *мм* лы патроннар, автомобиль амортизаторлары һәм тормоз шланглары, фармацевтика сәнәгате өчен роторлы пресслар, чуен һәм корыч коелмалар, нефть чыгару сәнәгате өчен җиһазлар керә. Пр-тиедә «POZIS»



«Серго исемендәге завод».
Көнкүреш суыткычлары җыю линиясе.

сәүдә маркасы б-н чыгарылучы күп кенә эшләнмәләргә Россиядә тиңнәр юк. 1990 еллар ахырыннан берләшмәнең Комплекслы конверсия программасы кысаларында Италиянең «Cannon» концерны җиһазлары һәм технологияләре нигезендә эштән туктатмыйча гына суыткыч техника җитештерүне реконструкцияләү бара, коючу производствосы модернизацияләнә. Яңа продукцияне проектлау һәм эшләп чыгаруны үзләштерү буенча тәҗрибә-эксперимент базасы булдырыла, халыкара ИСО-9002 стандарты нигезендә сыйфат контроле системасы гамәлгә кертелә. Суыткычлар һәм туңдыргычлар җитештерү күрсәткечләре (мең данә): 1996 да — 15,2, 1998 дә — 5,5, 1999 да — 26,9, 2000 дә — 111, 2001 дә — 170, 2002 дә — 238, 2013 тә — 278. Гомуми санда гражданлык продукциясенең өлеше 80% ка кадәр арта.

Пр-тиенең оборона продукциясе дөньяның 30 дан артык иленә, ш.и. Һиндстанга, Кытай, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Малайзия, Алжир, Финляндиягә, Көнчыгыш Европа илләренә һ.б.га җибәрелә. Көнкүреш суыткычлары БДБ илләренә чыгарыла. 2000 елларда пр-тиенең казанышлары «Россиянең иң яхшы 1000 предприятиесе», «XXI гасыр Россия машина төзелешенең иң яхшы 100 предприятиесе һәм оешмасы», ш.у. «БДБ илләренә иң яхшы экспортлаучысы» конкурслары дипломнары, 1 нче махсус халыкара «Автофургоннар һәм тагылмалар» күргәзмәсенең (Мәскәү, 2001) алтын медале һәм «Елның иң яхшы фургоны» дипломы һ.б. б-н бәяләнә. Шәһәр хасил итүче пр-тие. Поликлиникасы, санаторий-профилакторие, спорт сарае, стадионы, ярдәмче хуҗалыгы бар.

Ленин ордены (1971) һәм 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены (1985) б-н бүләкләнә. Күп кенә эшчеләре хөкүмәт бүләкләренә лаек була: 2 кешегә — Сов. Союзы Герое, 1 кешегә — Соц. Хезмәт Герое исемнәре, 8 кешегә — СССР Дәүләт бүләге, 1 кешегә Ленин комсомолы бүләге бирелә, 4 кеше Ленин ордены б-н бүләкләнә.

Завод җитәкчеләре — И.И.Гаврилов (1921–24), Л.Ф.Садовец (1930–31), А.В.Гаевский (1931–33), Т.Г.Зотов (1933–35), М.В.Хруничев (1935–37), Г.К.Волошинов (1937), В.В.Сытин (1938–39), Д.В.Белогур (1939–41), А.В.Саханицкий (1941–43), Г.И.Рудаков (1943–50), А.А.Абецедарский (1950–54), А.Ф.Тарасенко (1954–59), А.С.Шустов (1959–75), В.Х.Прохоренко (1975–80), В.И.Егоров (1980–81), Ю.И.Катков (1981–88), А.И.Горшков (1988–90), О.В.Филиппов (1990–96), В.А.Слепцов (1996–98), Р.Ш.Хәсәнов (1998 дән).

*Әд.:* Татарстан: Спец. вып. 2003. № 12.

*С.Г.Белов.*

**СЕРЕ́БРЕННИКОВ** Борис Александрович (6.3.1915, Архангельск губ., Холмогор өязе Холмогор а. — 28.2.1989, Мәскәү), тел галиме, филол. фән. д-ры (1956), СССР ФА академигы (1984; 1953 елдан мөхбир әгъза). Мәскәү тарих, филос. һәм әдәбият ин-тын тәмамлаганнан соң (1940), СССР ФАнең Тел белеме ин-тында: директор урынбасары (1950–55), директор (1960–64), гомуми тел белеме секторы мөдире (1964 тән), проф. (1969 дан). Хезмәтләре гомуми һәм чагыштырма-тарихи тел белеме мәсьәләләренә, Урал, төрки һәм һинд-европа телләренә карый. Төрки телләрдә төр, юнәлеш категорияләрен, морфологик күрсәткечләрнең килеп чыгышын өйрәнә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Категория времени и вида в финно-угорских языках пермской, волжской групп. М., 1960; Система времён татарского глагола. К., 1963; Историческая морфология мордовских языков. М., 1967; Вероятностные обоснования в компаративистике. М., 1974.

*Әд.:* Феоктистов А.П. 60-летие Б.А.Серебренникова // Советское финно-угроведение. 1975. № 1; Широков О.Е. Борис Александрович Серебренников // Вестн. Моск. ун-та. Сер. 9. Филология. 1989. № 4.

*Ф.Ә.Ганиев.*

**СЕРЕБРЯКО́В** Борис Ростиславович (29.10.1938, Баку ш. — 2001, Түбән Кама ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1970), проф. (1972). Әзәрбайҗан нефть һәм химия ин-тын тәмамлый (1960). 1962–90 да Бөтенсоюз түбән молекуляр олефиннар фәнни-тикшеренү ин-тында (Баку ш.) эшли, лаб. мөдире (1962 дән), бүлек мөдире (1972 дән), директор урынбасары (1976 дан), директор (1987 дән). 1990 нан «Түбәнкаманефтехим» АҖдә, баш инженер урынбасары, директор (1994 тән). Хезмәтләре органик синтезга ка-

рый. С. түбән олефиннарны гетероген каталитик ачыту технологиясен эшли. Пропиленны ачытып аммонолизлау ысулы б-н акрилонитрил таба, шуның нигезендә синтезланган суда эрүчән полимерлар нефть эшкәртү з-дларында коагулянтлар сыйфатында агынты суларны чистарту өчен кулланыла (Баку, Түбән Кама ш.). С. тәкъдим иткән пропилен оксиды һәм стирол җитештерү, югары октанлы бензин чыгару технологияләре «Түбәнкаманефтехим» АҖдә гамәлгә кертелгән. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нитрил акриловой кислоты. Баку, 1968; Высшие олефины. Л., 1984; Новые процессы органического синтеза. М., 1989.


**СЕРЕ́БРЯНЫЙ** (Серебряный-Оболенский) Василий Семёнович (? — 1568 тирәсе, Мәскәү), хәрби эшлекле, кенәз, бояр (1541), дворецкий (1549). 1541 елда Кырым ханы Сәхибгәрәйнең Мәскәүгә һөҗүмен кире кайтаруда катнаша. 1545 тә, 1545–51 еллардагы *Казанга рус дәүләтенең яулары* дәверендә, Казан янындагы сугышларда катнашкан отряд командиры. 1552 дә Казанны алганда каравыл полкының 1 нче (баш) воеводасы. С. җитәкчелегендә Яшерен Чишмә астына юл казыла (4 сентябрьдә шартлатыла). 2 октябрьдә Казанга һөҗүм вакытында Нурали капкасы янында барган сугыш б-н җитәкчелек итә. 1552 нең октябрендә — 1553 нең маенда Казанда 2 нче воевода. 1556–57 дә Зөя каласында 1 нче (баш) воевода. 1558–83 тәге Ливон сугышында Уң кул полкының 1 нче (баш) воеводасы (1558), Ливониядәге хәрби хәрәкәтләрдә (1559–67), Полоцк походында (1563) катнаша. 1564 тә Литвага яу вакытында 2 нче воевода, 1 нче (баш) воевода, П.И.Шуйский һәлак булганнан соң, армия б-н җитәкчелек итә, аны җиңелүдән саклап кала. *Е.В.Липаков.*

**«СЕРЕ́БРЯНЫЙ КОЛОКО́ЛЬЧИК»**, газета; к. *«Көмеш кыңгырау»*.

**СЕРЕ́БРЯНЫЙ** (Серебряный-Оболенский) Пётр Семёнович (? — 20.7.1570, Мәскәү), хәрби эшлекле, кенәз, бояр (1551). 1551–52 елларда Зөядә 2 нче воевода. А.Б.*Горбатый-Шуйский* б-н бергә шәһәр төзелешенә җитәкчелек итә: 1552 нең көзендә Казанны яулаганда *Япанчага* каршы сугышкан отряд командиры. 1558–67 дә Ливон орденына һәм Польшага каршы яуларда катнаша. 1569 да гаскәр башында Әстерханга килә, шуның б-н Кырым татарлары һәм төрекләрнең шәһәргә һөҗүмен булдырмый кала. Хыянәттә гаепләнә; Иван IV боерыгы б-н җәзалап үтерелә. *Е.В.Липаков.*

**СЕ́РИКОВ** Шамил Кәрим улы (5.3.1956, Алма-Ата — 22.11.1989, шунда ук), спортчы (грек-рим көрәше), СССРның атказ. спорт остасы (1979). Спорт б-н 1970 елда Алма-Ата шәһәрендә шөгыльләнә башлый, тренерлары — А.И.Алдабергенов, А.П.Шарков. СССР беренчелегендә (1974, яшүсмерләр арасында), мәктәп укучыларының Бөтенсоюз спартакиадасында (1974, 52 *кг* га кадәр авырлык категориясендә), И.М.Поддубный истәлегенә (1978, 57 *кг* га кадәр авырлык категориясендә) Халыкара турнирда җиңүче; СССР (1978), Европа (1979), дөнья (1978–79), Олимпия уеннары (1980, 57 *кг* га кадәр авырлык категориясендә) чемпионы. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**СЕРКӘБА́Ш** (Cephalanthera), сәхләбчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 14 төре билгеле, Евразиянең уртача поясында, ш.у. Төньяк Америкада таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — кызыл С. (C. rubra) Кама алдында һәм Кама арьягында очрый. Сирәкләнгән коры урманнарда, куаклар арасында, урман буйларында ялгызы гына яки зур булмаган төркемнәр хасил итеп үсә. Известьле туфракларны өстен күрә. 30–100 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы кыска. Сабагы кабыргалы, өске өлешендә аз гына төкчәле. Яфраклары ланцетсыман, очлы, сабакны уратып алганнар, кара яшел, аскы ягы соргылт. Чәчәкләре эре, куе кызыл, очлы чәчәк яфрагы куентыгында, нектары юк; өчпочмаклы калаклы алгы ирене аксыл төстә. Җимеше — тартмачык. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл (тамырларында барлыкка килгән бәбәкләр) б-н үрчи. Декоратив үсемлек. Югала баручы төр, ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Кызыл серкәбаш.

**СЕРО́ВА** Валентина Николаевна (25.10.1947, Кострома өлкәсенең Парфеньево р-ны Никола-Полома станциясе), химик-технолог, химия фән. д-ры (2000), проф. (2006). 1970 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. Хезмәтләре югары молекуляр кушылмалар химиясенә карый. С. металл катыш фрагментлары булган сополиметакрилатлар синтезының, ш.у. родамин 6Ж һ.б. лазер буягычлары б-н активлаштырылган сополиметакрилатларның синтезы һәм фотохимик искерүенең закончалыкларын ачыклый. Бергә полимерлашучы системаларда һәм тиңдәшле полимер матрицаларда (лазер нурланышы шартларында), стабилизаторлар сыйфатында металл тозларын, тиокарбамид һәм тиазолның ароматик кушылмаларын кулланып, буягычларның тотрыклылыгын күтәрү ысулларын тәкъдим итә. Полимер матрица буягычларында яңа лазер матдәләр таба (лазерлы-актив тирәлекләр). Уйлап табуга 13 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Структура и фотостойкость окрашенных родамином 6Ж металлосодержащих сополимеров метилметакрилата // Высокомолекулярные соединения. 1999. Т. 41А, № 6 (автордаш); Металлосодержащие сополиметакрилаты и материалы на их основе // Энциклопедия инженера-химика. 2008. № 6; Photo-Stabilization of Colorless and Colored Copolymer of Methylmethacrylate with Methacrylic Acid by (Thio)urea Derivatives // Russian Polymer News. 2001. V.6, № 3.

*Әд.:* Институт полимеров (полимерный факультет). 1971–2001: Краткий биогр. справ. К., 2001.

**СЕ́СПЕЛЬ** Мишши (псевд., чын исем-фамилиясе Кузьмин Михаил Кузьмич) (16.11.1899, Казан губ., Цивильск өязе Казаккасы а., хәзер Чуаш Респ-касының Канаш р-ны Сеспель а. — 16.6.1922, Украина ССРның Чернигов өлкәсе Старогородок а.), чуаш шагыйре, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе. Тәтеш укытучылар семинариясендә укый (1917–18). Мәскәүдә пропагандистлар һәм агитаторлар курсларын тәмамлаганнан соң, Тәтеш өязендә мәхкәмә-тикшерү комиссиясендә, РКСМ өяз ком-тында эшли. Чуаш комсомолын оештыручыларының берсе. 1920 елның көзендә Чабаксарга күчә, анда Чуаш автономия өлкәсе рев. трибуналының беренче рәисе, Чуаш өлкә ком-тының юстиция бүлеге мөдире. Силлабо-тоник шигырь төзелеше нигезләрен чуаш теленә яраклаштырып эшләп, аны чуаш поэзиясенә кертә. С. — агитатор шагыйрь, трибун. Иҗатының төп темасы — революция дошманнарына каршы көрәшкә, яңа тормыш төзүдә актив катнашырга чакыру — «Киләчәк», «Корычтай ышаныч», «Чуаш теле», «Чуаш улына», «Яшәү һәм үлем», «Чуаш кызына», «Үткән заман» һ.б. шигырьләрендә бигрәк тә ачык чагыла.

Ә с ә р.: Стальная вера. М., 1957.

*Әд.:* Писатели Советской Чувашии: Биобиблиогр. справ. Чебоксары, 1975; Михаил Сеспель: Биобиблиогр. указ.: В 2 ч. Чебоксары, 1989–2000; Х а р и с Р. Сеспель — заряд поэтического оптимизма // Время и перо. К., 2016.

*Р.К.Ганиева.*

**СЕ́ЧЕНОВО РАЙОНЫ́**, *Түбән Новгород өлкәсенең* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1929 елда Тёплый Стан р-ны буларак оештырыла, 1945 тән хәзерге исемен йөртә. Мәйданы — 1012,6 *км*². Үзәге — Сеченово авылы (Түбән Новгородтан 220 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 14784 кеше (2013), татарлар — 348 кеше (2010). Татарлар, тупланып, Кызыл Атау авылында (17 йөз башында Мишәр йортыннан күченүчеләр нигез сала) яшиләр. 1643 тә монда 42 йомышлы татар гаиләсе исәпләнә. Пётр I заманында алар дәүләт крәстияннәре катлавында санала һәм лашман хезмәтен үти. 1820 дә Кызыл Атауда 3 җамигъ мәчет була, 1866 да — дүртенчесе, 1868 дә бишенчесе ачыла. 20 йөз башында 6 мәчет, 2 мәдрәсә, 1 мәктәп, почта бүлекчәсе, 19 җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3294 дис. тәшкил итә. Халык саны: 1790 да — 931, 1859 да — 2121, 1870 тә — 2256, 1913 тә — 4439, 1925 тә — 4993 кеше. Кызыл Атау — К.Нәҗминең туган авылы; 1985 тә язучының музее оештырыла. Мәчет, авыл тарихы музее эшли. Урта мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. Ел саен *Сабан туе* уздырыла; спутник антенналары аша «Татарстан — Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе тапшырулары кабул ителә.

*Әд.:* Х а ф и з о в М.З. Нижегородские татары: Очерки истории. Н.Новгород, 1997; С е н ю т к и н а О.Н. Из истории нижегородской татарской деревни Красный Остров. Н.Новгород, 2005.

*Х.Ә.Габделкаюмов.*

**СЁМИНА** Ирина Ивановна (5.12.1956, Казан), фармаколог, мед. фән. д-ры (2000), проф. (2007). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1981), шунда ук фармакол. кафедрасында эшли, бер үк вакытта, 2006 елдан, менеджмент һәм югары белемле шәфкать туташлары әзерләү ф-ты деканы. Фәнни тикшеренүләре фармакол. өлкәсенә карый, фосфориллашкан карбон кислоталары гидразидларының ноотроп активлыгы механизмнарын өйрәнә. Уйлап табуга 7 патенты һәм 2 авторлык таныклыгы бар.

Хезм.: К вопросу о мембранных механизмах действия ноотропных препаратов // Биологические мембраны. 2001. Т. 18, № 5 (автордаш); Психотропная активность незамещённых производственных фосфорилацетогидразидов // Химико-фармацевт. журн. 2002. Т. 36, № 2 (автордаш).

**СИБАГАТУ́ЛЛИН** Айрат Миңнемулла улы (31.3.1958, Саба р-ны Байлар Сабасы а.), мәдәният эшлеклесе, ТРның һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (2007, 2009). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1987). 1977–81 елларда Чистай суднолар ремонтлау з-дында эшли. 1986–89 да Казан пед. ин-тының студентлар профкомы рәисе. 1989–91 дә КПССның Казан шәһәре Бауман район ком-ты инструкторы. 1991–93 тә «Киноцентр» бөтенроссия телевизион ҖБнең Татарстан бүлеге директоры урынбасары (Казан). 1993–97 дә ТРның кинематография буенча Дәүләт ком-ты рәисе урынбасары. 1997–98 дә ТР МК Аппаратының бүлек башлыгы. 1998–99 да ТР Премьер-министры киңәшчесе. 1999–2002 дә «Татарстан» Дәүләт телерадиотапшырулар компаниясе рәисенең 1 нче урынбасары, 2002–05 тә — рәисе, 2005–11 дә директоры. 2011 дән ТР мәдәният министры. Медальләр б-н бүләкләнә.

**СИБА́Й** шәһәре, *Башкортстан Республикасының* көньяк-көнчыгыш өлешендә, Уфа шәһәреннән 464 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 1938 елда эшче посёлок буларак нигез салына, 1955 тән — шәһәр. Халкы — 63603 кеше (2013). Татарлар саны: 1970 тә — 4440, 1979 да — 4442, 1989 да — 4922, 2002 дә — 5283, 2010 да 4734 кеше. Балалар сәнгать мәктәбе каршында «Очкын» хореографик бию ансамбле эшли, аның репертуарында, башка биюләр б-н бергә, татар биюләре дә бар. 2010 да С. да Әлмәт татар драма театры гастрольләре уза.

**СИБА́Т** Рафаэль Хуҗа улы, к. Р.Х.*Хуҗин*.

**СИБӘГА́ТОВ** Радик Гали улы (29.5.1934, БАССРның Балтач р-ны Иске Балтач а. — 6.5.2005, Уфа ш.), тел галиме, филол. фән. д-ры (1988), проф. (1989), Башкортстан һәм Татарстан Респ-каларының атказ. фән эшлеклесе (1993, 2004). Бөре пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1958), «Кызыл таң» г-тасы (Уфа) редакциясендә эшли. 1966 елда Ленинград югары партия мәктәбен тәмамлый. 1970 тән Башкорт ун-тында (1988 дән татар филологиясе каф. мөдире). Хезмәтләре тәрҗемә теориясенә, хәзерге татар теле синтаксисына, социолингвистикага карый.

Хезм.: Рус теленнән татар теленә тәрҗемә методикасының нигезләре. Уфа, 1979; Основные признаки предложения (на материале татарского языка). Уфа, 1980; Татары Башкортостана: Проблемы языка, истории, культуры. К., 2002.

*Әд.:* Миңнеәхмәтов Р. Гали углы — гали зат // Тулпар. 2004. № 2; Рамазанова Д.Б. Тарихыбыз сәхифәләрен актарганда // Мәйдан. 2007. № 6.

*И.М.Низамов.*

**СИБӘГАТУ́ЛЛИН** Фатих Сәүбан улы (1.5.1950, Арча р-ны Апаз а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, вет. фән. д-ры (1996), РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1997), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2010). Казан вет. ин-тын (1973), Саратов Югары партия мәктәбен (1987) тәмамлый. 1973–74 елларда Зеленодольск р-ны «Бишнә» с-зында баш вет. табибе. 1974–83 тә Балтач р-нында: Чапаев исем. к-зда баш вет. табибе (1978 гә кадәр), 1978–80 дә «Правда» к-зы рәисе, 1980 нән КПСС райкомының 2 нче секретаре. 1983–84 тә Халык депутатларының Арча район советы башкарма ком-ты рәисе. 1984–90 да КПССның Мамадыш райкомы 1 нче секретаре. 1991–96 да ТР а.х. һәм азык-төлек министры. Бер үк вакытта, 1995–96 да, ТР премьер-министры урынбасары. 1996–2007 дә Нурлат р-ны һәм Нурлат ш. хакимияте башлыгы; Нурлат берләштерелгән халык депутатлары советы рәисе, бер үк вакытта, 2006 дан, Казан аграр ун-ты профессоры. РФ Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты (2007 дән). С. респ-ка а.х. үсешенә (а.х. культураларының уңышын арттыру, терлекчелекнең нәтиҗәлелеген күтәрү) җитди өлеш кертә. Ул җитәкчелек иткән елларда Нурлат р-ны респ-када ашлык җитештерү, терлекчелек күрсәткечләре буенча алдынгы урыннарны били. Әлеге чорда Нурлатта һәм районның башка торак пунктларында социаль-мәдәният һәм көнкүреш объектларын реконструкцияләү, яңарту һәм яңаларын төзү буенча зур күләмдә эшләр башкарыла. Нурлатта үзәк мәйдан реконструкцияләнә, концертлар залы булган, 300 укучыга исәпләнгән Балалар сәнгать мәктәбе, гомуми белем бирү мәктәпләре (1296 һәм 650 урынлы), һөнәри лицей (540 урынлы), тимер юл вокзалы, очу-утырту полосалы аэропорт, Мәдәният сарае, Яшьләр үзәге, Спорт сарае (1500 урынлы) сафка баса; район телетапшырулары оештырыла. Барлык торак пунктларда диярлек йортларга газ кертү гамәлгә ашырыла, Мамык, Рус Богдашкиносы, Каравыл Тавы авылларында суүткәргеч төзелә, берничә торак пунктта мәдәният йортлары барлыкка килә. Фәнни хезмәтләре вет. эшен, нәсел-токымга бәйле эшләрне оештыру һәм законнар б-н көйләү мәсьәләләренә, базар икътисады шартларында ТР да терлекчелекнең һәм аграр секторның үсеш үзенчәлекләренә багышлана. ТРның Дәүләт бүләге (2000) уҗым арышының югары уңыш бирә торган сортларын китереп чыгаруда һәм тиз арада производствога кертүдә катнашканы өчен бирелә. Татар халкының борынгы чор, урта гасырлар тарихына һәм дөньяда төрле диннәрнең җәмгыять тормышында тоткан урыны һәм роленә багышланган тарихи публицистик хезмәтләр авторы. 1985–95 тә ТАССР, ТССР, ТР ЮС депутаты, 1995–2004 тә ТР халык депутаты. Халыклар дуслыгы, «Почёт», «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Болезни животных, передающиеся от животных к человеку. К., 1994 (автордаш); Ветеринарная служба и рыночная экономика. К., 1994 (автордаш); Развитие сельскохозяйственной кооперации. К., 1998 (автордаш); Совершенствование холмогорского скота в Татарстане. М., 2001 (автордаш); От Атиллы до президента: В 2 кн. К., 2008; «Великие татары — строители и защитники государства российского». К., 2012.

*Әд.:* Созидатель. К., 2010.

**СИБГАТУ́ЛЛИН** Әмир Сөләйман улы (2.9.1948, Балык Бистәсе р-ны Яңа Арыш а.), композит конструкцияләр механикасы өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (2002), проф. (2003). Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый (1972), шунда ук эшли. 1988 дән Казан ун-тының Чаллы ин-тында, төзелеш технологиясе каф. мөдире (2002 дән). С. конструкцияләрдәге анизотроп һәм композит элементларның (сүрүләр, пластиналар, бруслар) күп цикллы йөкләнешләргә чыдамлыгы һәм җимерелүенең яңа критерийларын, ш.у. ярылулар механикасында яңа критерийлар тәкъдим итә. Анизотроп һәм композит сүрүләр, пластиналар, брусларның кыска һәм озак вакытлы статик яки күп циклы йөкләнешләргә, югары темп-ралар тәэсиренә чыдамлыгын билгеләү алымнарын эшли.

Хезм.: Предельное состояние слоистых композитных оболочек при совместном действии статических и циклических нагрузок // Изв. РАН. Механика твёрдого тела. 1994. № 4 (автордаш); Об универсальности критерия разрушения // Изв. РАН. Механика твёрдого тела. 2002. № 6; Расчёт конструкций по теории предельного равновесия. К., 2003 (автордаш).

**СИБГАТУ́ЛЛИН** Җәлил Җәмил улы (20.10.1959, Актаныш р-ны Пучы а.), педиатр, психиатр, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999), мед. фән. канд. (1992). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1983), Респ-ка психиатрия хастаханәсендә табиб булып эшли. 1987 елдан Казан ГИДУВында. 1992 дән «Шифа» агросәнәгать фирмасы фәнни консультанты. 1993 тән «Сәмруг» АҖнең идарә рәисе. Хезмәтләре балалар һәм яшүсмерләр наркологиясенә, психоэндокринологиягә, соматопсихиатриягә карый. Дәүләт бүләге «Сәламәтлек резервы скринингы һәм кече яшьтәге балаларны сәламәтләндерүнең комплекслы системасында «Винибис» препаратын куллануны фәнни нигезләү» («Скрининг резерва здоровья и научное обоснование применения препарата «Винибис» в комплексной системе оздоровления детей раннего возраста») хезмәте өчен бирелә.

**СИБГАТУ́ЛЛИН** Кадыйр (Минкадыйр) Һидият улы (15.2.1942, Балык Бистәсе р-ны Балыклы Чүкәй а. — 4.6.1994, Чаллы ш., Балык Бистәсе р-нының Кече Укмас авылында җирләнә), шагыйрь. Казан ун-тын тәмамлый (1972). 1957–65 елларда (бүленеп) Казан органик синтез з-дында эшли. 1966–72 дә Балык Бистәсе р-ны «Октябрь юлы» г-тасы редакциясендә әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире. 1978 дән Чаллы шәһәрендә яши. 1993 кә кадәр ТР Язучылар берлегенең Чаллы бүлегендә. «Әманәт» (1974), «Гамь» (1976), «Аваз-



Л.С. Сибгатуллин.

лар» (1981), «Инану» (1988), «Гомерем дулкыннары» (1993), «Намазлык» (Чаллы, 1994), «Әйтте шагыйрь» (2002) һ.б. җыентыклар авторы. С.ның туган якка, аның табигатенә, мәхәббәткә, авыл хезмәтенә багышланган шигырьләренә дә, социаль юнәлешле әсәрләренә дә нечкә лиризм хас. Ул тормышны киеренке, четерекле каршылыкларында ачарга омтыла, фәлсәфи уйларга төреп бирә. Аның кайбер шигырьләре, композиторлар Р.Бакиров, И.Закиров, С.Чуганаев тарафыннан көйгә салынып, популяр җырларга әверелә.

Ә с ә р.: Бер ноктада. К., 2007; Осенняя весна. К., 1999.

*Әд.:* С а ф и н Ф. Кече Укмаска сәяхәт // Казан утлары. 1999. № 11; Г а л и у л л и н Т. Шигърият офыклары // Татар шигърияте: 1980–2000 еллар. К., 2003.

**СИБГАТУ́ЛЛИН** Лотфулла Сибай улы (15.3.1912, Пермь өлкәсенең Уинск р-ны Чайка а. — 6.10.1978, Үзбәкстан ССР, Ташкент өлкәсе Югары Чирчик р-ны Паркент а.), Сов. Союзы Герое (16.10.1943), капитан. Свердловск пед. техникумын (1934), Горький хәрби-сәяси уч-щесен (1945) тәмамлый. 1938 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 229 нчы укчы полкта батальон командирының сәяси эшләр буенча урынбасары (13 нче армиянең 8 нче укчы дивизиясе). Үзәк һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Гомель-Речица (1943) һәм Висла-Одер һөҗүм операцияләрендә (1945) катнаша. Югары Жары авылы (Украина ССР, Гомель өлкәсе Брагин р-ны) янында Днепр елгасын кичеп чыкканда батырлык күрсәтә: 1943 нең 22 сентябрендә бер төркем сугышчылар б-н дошман уты астында елганы кичеп чыга, плацдармны яулап ала һәм, аны ныгытып, совет гаскәрләре кичүенә юл ача. 1946 дан запаста. Паркентта адм.-хуҗалык эше б-н шөгыльләнә. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Паркентта бер урам С. исемен йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СИБГАТУ́ЛЛИН** Марат Нәби улы (25.5.1947, Мамадыш ш.), урман хуҗалыгы инженеры, ТРның атказ. урманчысы (1994), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Мари политехник ин-тын тәмамлый (1986). 1962 елдан Саба урманчылыгында. Дәүләт бүләге урман кискәндә урман байлыгын саклап калуны, йомшак яфраклы һәм вак товарлыклы агачларны тирәнтен эшкәртүдә алдынгы ысуллар кертүне оештыруда, Саба урман хуҗалыгында чыршылар үстерүнең стадияләрен тизләтүдә катнашканы өчен бирелә.

**СИБГАТУ́ЛЛИН** Наил Рәхим улы (27.5.1943, Казан — 12.3.2004, Мәскәү), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1979), проф. (1985). Казан ун-тын тәмамлый (1965), Мәскәү ун-тында эшли, гидромеханика каф. профессоры (1985 тән). Хезмәтләре механикага һәм гидродинамикага, астрофизикага, ихтималлыклар теориясенә карый. С. авиация сәнәгате өчен газ б-н майлаулы платформалар теориясен эшли. Нәсызыкча сыгылмалылык һәм магнитик газ динамикасы модельләренең матем. аналогиясен ачыклый. Аркылы тирбәнүләрнең эластик катламнарда бәрмә дулкыннар ясап резонанс барлыкка китерү күренешен билгели. Әйләнүче нейтрон йолдызларның электромагнит һәм гравитация кырларын гомуми ихтималлыклар теориясендә төзү алымын эшли.

Х е з м.: Колебания и волны в сильных гравитационных и электромагнитных полях. М., 1984; Платформы на газовой смазке. М., 1987 (автордаш); Oscillations and waves in strong gravitational and electromagnetic fields. B., 1991.

**СИБГАТУ́ЛЛИН** Рафаэль Сәгыйдулла улы (20.3.1937, Сарман р-ны Зур Нөркәй а.), вет. эпизоотологы, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1996), вет. фән. канд. (1969), ТАССРның атказ. вет. табибе (1988). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1967), шунда ук эшли. Фәнни тикшеренүләре түләмә авыруы иммуногенезына һәм авыруны кисәтүгә, туберкулинга гадәти булмаган реакцияләрнең табигатен өйрәнүгә, аларны дифференциацияләүгә һәм, иммуномодуляторлар кулланып, мөгезле эре терлекләрдә вакцинадан соң туберкулинга каршы иммунитетны көчәйтүгә карый. Дәүләт бүләге мөгезле эре терлек һәм дуңгызларда туберкулёзга диагноз кую, авыруны дәвалау һәм кисәтү буенча чаралар комплексы эшләүдә катнашуы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Практикум по эпизоотологии и инфекционным болезням с ветеринарной санитарией. М., 2002 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**СИБГАТУ́ЛЛИН** Ростислав Имам улы (31.8.1923, Украина ССР Шепетовка ш.), генерал-майор (1977). Ульянов танк уч-щесен (1944), В.И.Ленин исем. хәрби-сәяси академияне (Мәскәү, 1953), Югары акад. ракета курсларын (Мәскәү, 1959) тәмамлый. 1942 елдан Кызыл Армия сафларында. 1944–49 да Ульянов танк уч-щесендә уку-укыту взводы командиры, комсомол эшләре буенча сәяси бүлек башлыгы ярдәмчесе. 1954–81 дә Балтыйк буе хәрби округында: округ сәяси идарә башлыгының комсомол буенча ярдәмчесе, 1957–59 да 4 нче армия корпусында сәяси бүлек башлыгы урынбасары, 1959–60 та ракета берләшмәсендә сәяси бүлек башлыгы, 1960–75 тә армия сәяси бүлеге башлыгының 1 нче урынбасары, 1975–81 дә штаб һәм идарәнең сәяси бүлек башлыгы һәм округ штабының сәясәт буенча башлык урынбасары. 1982 дән запаста, Уфа шәһәрендә яши. 1994 тән БР Хәрби хезмәт һәм сугыш ветераннары ком-ты бюросы әгъзасы. Кызыл байрак, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**СИБГАТУ́ЛЛИН** Хәкимулла Сибгат улы (1.12.1948, Балтач р-ны Иске Салавыч а.), агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. а.х. хезмәткәре (1986). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), Балтач р-нында: «Победа», «Социалистик Татарстан» г-тасы исем. к-зларда баш агроном (1973 тән), «Дружба» к-зы рәисе урынбасары, «Правда» к-зы рәисе (1984 тән), район башкарма ком-тының а.х. идарәсе башлыгы (1985 тән), Ленин исем. к-з рәисе (1996 дан, хәзер «Сорнай» ҖЧҖ). С. җитәкче булганда Ленин исем. к-зда 50 дән артык җитештерү һәм социаль-мәдәният объектлары төзелә. 2001–07 дә бөртекле культураларның уртача уңышы 1 *га* дан 43,4 *ц* га, бәрәңгенеке — 155 *ц* га җитә, еллык савым һәр сыердан уртача 6412 *кг* тәшкил итә. Медаль б-н бүләкләнә.

**СИБГАТУ́ЛЛИН** Шәүкәт Гаделша улы (псевд. Шәүкәт Гаделша) (16.9.1949, Төмән өлкәсенең Түбән Тәүде р-ны Киндерле а.), шагыйрь. Казан ун-тын тәмамлый (1983). Колхозда, КАМАЗ төзелешендә эшли. 1981 дән Казанда яши, төзелештә эшли. С.ның шигърияте Себер татарлары фольклоры йогынтысында формалаша. «Ярык мөгез» (1997), «Ядрә тигән» (1998), «Сөмән кадыйм» (2000), «Җилгә моң дыңгычлыйм» (2003), «Аучы җыры» (2004), «Чоңгыл» (2006) исемле шигырь җыентыклары авторы. Иҗатының төп темасы — Себер табигате һәм аның кешеләре.

*Әд.:* Ф ә и з о в а Л.Х. Язмышының дәрьясы — Казан–Төмән арасы... К, 2008.

**СИБГАТУ́ЛЛИНА** Әлфинә Таһир кызы (5.7.1962, Сарман р-ны Карашай-Саклау а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2000), проф. (2002). Алабуга пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1984), шунда ук эшли. 2005 елдан РФАнең Көнчыгышны өйрәнү ин-тында фәнни хезмәткәр, 2010 нан М.Горький исем. Дөнья әдәбияты ин-ты өлкән фәнни хезмәткәре. Бер үк вакытта, 2005–13 елларда, Мәскәү пед. ун-тында укыта. Хезмәтләре 19 йөз поэзиясе (Г.Кандалый, Акмулла), суфичылык әдәбияты, Россия мөселманнарының Госманлылар империясе б-н багланышлары, 19–20 йөзләрдә Россиядән хаҗга бару тарихына бәйле. Төрек теленнән татар теленә К.Җаманаклы, Г.Баттал-Таймас әсәрләрен тәрҗемә итә.

Х е з м.: Суфичылык серләре (төрки-татар шигъриятендә дини-суфичыл символлар, образлар, атамалар). К., 1998; Илаһи гашыйклар юлыннан: Суфичылык турында очерклар. К., 1999; В поисках человека (концепция личности в татарской поэзии XIX века). Елабуга, 2001; Контакты тюрок-мусульман Российской и Османской империй на рубеже XIX–XX вв. М., 2010.

*Әд.:* И с м ә г ы й л е в а С. Серләр дөньясында ачышлар бар // Фән һәм мәктәп. 1999. № 7–8; Х ә й р у л л и н а В. Үзебезнеке // Мәйдан. 2005. № 3.

**СИБГАТУ́ЛЛИНА** Ирина Фәһим кызы (3.6.1965, Мәскәү өлкәсе Шатура ш.), психолог, психол. фән. д-ры (2002), проф. (2006). Казан ун-тын тәмамлый (1987). 1990 елдан ТРның Мәгарифне үстерү ин-тында, 2000 нән пед. һәм психол. каф. мөдире. Хезмәтләре сәләтле кешеләр психикасының үсеш диссинхрониясе мәсьәләләренә карый.

Хезм.: Одарённый ребёнок в развитии, общении, учении, или что можно сказать об одарённости сегодня. К., 1997 (автордаш); Мышление, интеллект, одарённость: вопросы теории и технологии. К., 2005 (автордаш); Психологическая безопасность, культура и качество жизни в мегаполисе. К., 2008; Образование, устремлённое в будущее. К., 2016 (автордаш).

**СИБИ́Р**, к. *Кашлык*.

**«СИБИ́РИЯ»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. 1912 елның 18 февраленнән 1913 нең 31 августына кадәр Томск шәһәрендә атнага 3–4 тапкыр татар телендә нәшер ителә, барысы 145 саны чыга. Себердәге беренче татар газетасы. Нашире һәм мөхәррире — М.Нәүрүзов, аннан соң Ф.Нәүрүзова. «С.» үзенең максаты итеп татар милләтенә хезмәт итүне куя. Татар халкының милли үзаңын, татар мәдәниятен үстерү өчен көрәшә. Актив авторлары арасында — Г.Абдуллин, Ш.Әхмәтҗанов, Н.Әхмәтов, И.Биккулов, Г.Борнаев, С.Ибраһимов, З.Кадыйри, Н.Кариев, Н.Карпов, М.Мозаффария, Н.Сәитов, Ф.Сөләймания, А.Туктабаев, Ф.Фәрит, Г.Хөсәенов, Ш.Якупов һ.б. Эчке һәм тышкы сәясәткә, икътисад һәм сәүдәгә, урта һәм югары белемгә, татар мәдәниятенә багышланган мәкаләләр басыла. Газета укучыларны Россиянең төрле төбәкләре: Бурятия, Казакъстан, Кыргызстан, Якутия, Байкал аръягы, Сахалин һәм Оренбург, Уральск, Чиләбе һ.б. шәһәрләр мөселманнары тарихы һәм гореф-гадәтләре б-н таныштыра. Күренекле шәхесләрнең биографияләре, фельетоннар, Ф.Ибраһимов, С.Кадрия, С.Сүнчәләй, Г.Тукай шигырьләре басыла. Татар музыкасы һәм театры турындагы материалларга зур урын бирелә. Даими рубрикалары: «Хатын-кызлар дөньясында», «Себер яңалыклары», «Мәктәп балалары өчен уку ярдәмлеге», «Югары уку йортлары һәм студентлар», «Татар дөньясы», «Файдалы киңәшләр» һ.б. Ш.у.к. *«Тормыш»*.

**СИБИ́РКИН** Анатолий Сергеевич (30.6.1907, Мәскәү — 10.1970, Казан), инженер-технолог, Казандагы 16 нчы з-д директоры (1955–60, 1963–67), Соц. Хезмәт Герое (1966), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1960). Мәскәү механика техникумын (1929), Мәскәү авиация сәнәгате академиясен (1941) тәмамлый. 1929–30 елларда «Текстильстрой»да сызымчы-конструктор; 1930–45 тә 132 нче з-дта (Мәскәү; 1941 дә завод Чиләбе өлкәсенең Сим шәһәренә эвакуацияләнә) конструктор, конструкторлар төркеме башлыгы, цех, бүлек башлыгы урынбасары, баш конструктор, баш инженер. 1945–55 тә 38 нче з-д (Омск ш.) директоры. ТАССР ХХС рәисенең 1 нче урынбасары (1960–63). 1967–70 тә Казан авиация ин-тының сәнәгать икътисады һәм җитештерүне оештыру каф. доценты. С. җитәкчелегендә яңа техника үрнәкләре эшләнә, яңа технологияләр гамәлгә кертелә, РД-3М авиация һәм турбореактив двигательләр конструкциясен камилләштерү һәм ышанычлылыгын арттыру буенча зур эш башкарыла, тәҗрибә моторларын җитештерү һ.б. үзләштерелә. Герой исеме җидееллык планны (1959–65) үтәүдә зур казанышлары һәм яңа техника эшләве өчен бирелә. 1959–70 тә ТАССР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. *А.А.Козин.*



А.С. Сибиркин.

**СИВА́ЛЬНЕВ** Евгений Николаевич (12.12.1887 – 4.8.1955, Казан), самолётлар төзү өлкәсе галиме, авиация җитештерүен оештыручы, проф. (1939). 1918 елда Петроград технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Петроград һәм Таганрог авиация з-дларында техник директор булып эшли; И.И.Сикорский, Д.П.Григорович, Н.Н.Поликарпов, А.Н.Туполев һ.б.ның самолёт җитештерүне оештыру технологияләрен, ш.и. легендар «Илья Муромец», У-2 (По-2), И-2, АНТ-7 җитештерүне камилләштерүдә катнаша. 1936 дан Казанда, авиация з-ды төзелешенең проект җитәкчесе (1936–38); бер үк вакытта (1937 дән) Казан авиация ин-тында, самолётлар төзү каф. мөдире (1938–55), директор урынбасары (1939–41). С. җитәкчелегендә детальләрне пластик формалау юлы б-н әзерләүдә заманча җиһазларның нигезен тәшкил иткән КАИ-1, КАИ-2 (РО-1), КАИ-5, КАИ-7 тышлау пресслары эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанский авиационный институт. К., 1982; Дегтярёв Г.Л., Сафариев М.С. Казанский государственный технический университет им. А.Н.Туполева: Люди и вехи истории. К., 2002.

**СИГА́Л** Евгений Иосифович (22.1.1952, Казан), онколог, мед. фән. д-ры (2000), ТРның һәм РФнең атказ. табибе (2001, 2008). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1975), Казан шәһәренең 15 нче хастаханәсендә эшли. 1976 елдан Респ-ка онкология клиник диспансерында табиб-онколог, 1988 дән үңәч һәм ашказаны хирургиясе бүлеге мөдире, бер үк вакытта «Эндоскопик хирургия» уку-укыту үзәгенең хирургия һәм онкология каф. профессоры. Хезмәтләре үңәч хирургиясенә, корсак куышлыгы эндоскопик хирургиясенә карый. С. корсак куышлыгына лапароскопик операцияләр ясау, үңәчнең күкрәк өлеше яман шешләрен катнаш дәвалау ысулларын эшли. Уйлап табуга 3 патенты һәм 4 рационализаторлык тәкъдиме бар.

Хезм.: Осложнения хирургии грыж живота: Учеб. пособие. М., 2005 (автордаш); Оперативная лапароскопия в хирургии, гинекологии и урологии. М., 2007 (автордаш); Эндоскопическая хирургия. М., 2009 (автордаш).

**СИГА́Л** Иосиф Зельманович (9.7.1923, Украина ССРның Каменец-Подольск ш. — 6.10.2001, Казан), хирург-фтизиатр, мед. фән. д-ры (1969), проф. (1970), ТАССРның атказ. табибе (1957). 2 нче Мәскәү мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1944), Бөек Ватан сугышы фронтларында. 1945–47 елларда Германиядәге сов. гаскәрләре төркеменең мед.-сан. частенда хезмәт итә. 1948 дән Казанда: 5 нче шәһәр хастаханәсендә хирургия бүлеге мөдире, 1950 дән Респ-ка туберкулёз диспансерында фтизиохирургия бүлеге мөдире, 1960 тан Казан мед. ин-тының туберкулёз курсы кафедрасында. 1963–85 тә Казан ГИДУВында. Респ-ка туберкулёз диспансеры каршында Идел буенда беренче фтизиохирургия бүлеген оештыручы (1952). Хезмәтләре үпкә туберкулёзы хирургиясенә, туберкулёзга диагноз кую һәм авыруны дәвалау өлкәсендәге тикшеренүләрнең бронхолитик ысулларына карый. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Поддиафрагмальный пневматический пелот // Проблемы туберкулёза. 1953. № 6; Опыт реакции лёгкого и его частей при туберкулёзе // Казан. мед. журн. 1958. № 4; Рёберные кусачки // Новый хирург. архив. 1958. № 4; Опыт торакоакустики у больных туберкулёзом лёгких // Казан. мед. журн. 1961. № 1.

*Әд.:* Фёдоров И.В. Врачебная династия Сигал. 1993. К., 2007.

**СИГА́Л** Мойше Зельманович (14.1.1920, Украина ССРның Каменец-Подольск ш. — 2.10.1990, Казан), хирург-онколог, мед. фән. д-ры (1964), проф. (1966), ТАССРның һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1973, 1981). Акад. А.Д.Адо шәкерте. Донецк мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1941), СССР НКВДсының Печора тимер юл төзелеше лазаретында хирург, баш табиб (Коми АССР, Печора ш.) 1944 елдан ТАССР НКВДсы хастаханәсендә. 1945–90 да Казан ГИДУВының хирургия һәм онкология кафедрасында, 1967 дән каф. мөдире. Казан онкологлар мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Операция юлы б-н диагноз куюның яңа юнәлешенә — трансиллюминациягә нигез сала, яман шеш хирургиясенең аңарчы өйрәнелмәгән мәсьәләләрен тикшерә, ашказанына һәм эчәклеккә асептик электрохирургия операцияләре, онкологиядә иреклe тире пластикасы методикаларын эшли. СССРда беренче булып аутоаллергия мәсьәләләрен өйрәнә. Хезмәтләре кушыш әгъзалар хирургиясенә карый. Уйлап табуга 20 патенты бар. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Хезм.: Трансиллюминация при операциях на половых органах. М., 1974; Свободная кожная пластика в онкохирургии. К., 1981 (автордаш); Гастроэктомия и резекция желудка по поводу рака. К., 1991 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Мойше Зельманович Сигал // Казан. мед. журн. 1991. № 2.

**СИГИ́ТОВА** Ольга Николаевна (13.11.1949, Мурманск өлкәсенең Кировск ш.), нефролог, мед. фән. д-ры (2000), проф. (2001), ТРның атказ. табибе (2002). Казан мед. ин-тын



В.И.Сигов.

тәмамлаганнан соң (1973), Казан шәһәрендәге 6 нчы хастаханәдә эшли. 1974 елдан Әлмәт участок хастаханәсе терапевты. 1982 дән Казан мед. ин-тының эчке авырулар кафедрасында, 2003 тән гомуми табиблек практикасы каф. мөдире. Хезмәтләре күзәнәк-ялкынсыну механизмнарын, нефроцитларга зыян китерүче факторлар тәэсирен өйрәнүгә, гломерулонефритны димефосфон кулланып дәвалауга (фосфолипидурияне исәпләү формуласын эшли), мед. практикасына гломерулонефритның активлыгын бәяләү комплексы методын кертүгә карый.

Х е з м.: Клинический и мембраностабилизирующий эффекты димефосфона и преднизолона и/или циклофосфона при лечении активного гломерулонефрита // Казан. мед. журн. 1999. № 5 (автордаш); Об информативности иммуно-мембранных показателей активности гломерулонефрита и эффективности мембраностабилизатора димефосфона // Терапевт. архив. 1999. № 6 (автордаш).
*В.Ф.Богоявленский.*

**СИ́ГОВ** Василий Иванович (22.6.1919, хәзер Омск өлкәсенең Тюкалин р-ны Белоглазово а. — 27.1.1987, Чистай ш.), Сов. Союзы Герое (14.9.1945), 1 нче статья старшина. Туган авылында колхоз эшендә, Камчаткада балык промыселында катер мотористы, Петропавловск портында төзүче һәм судноларны җыючы булып эшли. 1939–43 елларда һәм 1945 тән Кызыл Армия сафларында. 1945 тә совет-япон сугышында катнаша, Камчатка Хәрби флотилиясендә үзйөрешле баржа экипажы командиры. Тын океан флоты составында Курил десанты операциясендә катнаша. 1945 нең августында Курил утравындагы сугыш хәрәкәтләрендә батырлык күрсәтә: 3 көн дәвамында сугыш кораллары һәм десантчылар өчен кирәк-яраклар ташый. Яралана, шулай да десантчыларны утрауга төшергәнче сафта кала. 1946 да демобилизацияләнә. Петропавловск портында, соңыннан Долинск шәһәрендә (Сахалин өлкәсе) азык комб-тында эшли. 1970 нең ахырында Чистай шәһәренә күченеп кайта. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.
*М.З.Хәбибуллин.*

**СИДЕ́ЛЬНИКОВА** Татьяна Тимофеевна (6.1.1951, Казан), педагог, политолог, филос. фән. канд. (1979), пед. фән. д-ры (2007), проф. (2009). 1973 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1975 тән фәнни коммунизм (1989 дан политология) кафедрасында укыта, 2003 тән гамәли политология кафедрасында. Хезмәтләре актив укытуның инновацион технологияләренә, уку программаларын мультимедиа чаралары б-н тәэмин итүгә, соц.-сәяси риторикага өйрәтү проблемаларына карый.

Х е з м.: Спор! Спор? Спор... К., 1992; Инновационный потенциал принципа наглядности в изучении гуманитарных наук на примере курса «Политология». К., 2005; Инновации в обучении социальным и гуманитарным дисциплинам: вопросы теории и практики (на примере курса «Политология»). К., 2009.

**СИДЕРА́ЛЬ АШЛАМА́**, к. *Яшел ашламалар.*

**СИДЕРИ́Т**, т и м е р ш п а т ы, минерал, $FeCO_3$, Mn, Mg, Ca, CO, Zn кушылмаларының күләменә бәйле рәвештә аерым төрләр хасил итә, кристаллар, агрегат һәм конкрецияләр рәвешендә очрый. Кызгылт төсмерле ак, аксыл яки куе көрән (кара диярлек) төстә. Пыяласыман ялтыравыклы. Үтә күренмәле. Катылыгы 4–4,5. Тыгызлыгы якынча 4,2 *г/см³*. С. утырма тышлыкта киң таралган. Кайнар су эремәләреннән һәм салкын диңгез бассейннарында барлыкка килә. ТР терр-ясендә борынгы заманнардан (урта девон, 385 млн. ел) хәзерге заманны да кертеп барлык утырма токымнарда, чуерташ, конкреция, балчыксыл мергель конкрецияләрендә, оолитлы сидерит-шамозитлы токымнар катламнарында кунык рәвешендә очрый. Тимер рудасы буларак кулланыла.

*Әд.:* Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003.

**СИДО́РКИН** Владимир Валентинович (16.4.1957, Ленинград), гидрогеолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004), геол.-минерал. фән. канд. (1992). Ленинград тау ин-тын тәмамлаганнан соң (1979), «Дальгеология», «Амургеология» геол. җитештерү берләшмәләрендә (Амур өлкәсенең Тында ш.) эшли. 1991 елдан «Гидрогеология һәм геоэкология компаниясе» АҖдә (Мәскәү). Дәүләт бүләге Татарстан терр-ясендә эчәргә яраклы җир асты суларын эзләү һәм запасларын бәяләү алымнарын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**СИ́ДОРОВ** Антон Петрович (Антон Петров) (1830, Казан губ., Спас өязе Рус Бизнәсе а. — 19.4.1861, шунда ук), крепостной крәстиян, Бизнә крәстияннәре кузгалышы җитәкчесе. Укымышлы була, дини һәм дөньяви китаплар укый. 1861 елның апрель башында Рус Бизнәсе крәстияннәре С.тан 1861 елгы крәстиян реформасы турындагы 1861 ел 19 февраль «Нигезләмә»сен («Положение от 19 февраля 1861 г.») укып аңлатуын үтенәләр. С. фәрманны үзенчә аңлата: патша крәстияннәрне 1858 дә үк «чын иреккә» чыгарган, ә алпавытлар ул карарны халыктан яшереп килгәннәр, ди. Шунлыктан алпавытлар кулындагы җир һәм урманнар күптәннән крәстияннәрнеке, авыл халкы аларга бил бөгәргә тиеш түгел, дигән сүз тарата. Болай итеп аңлату крепостной крәстияннәрнең өметләренә туры килә. «Чын ирек» турында хәбәр Казан губернасының Спас, Лаеш, Чистай өязләрендә, күрше Самара, Сембер губерналары өязләрендә тарала, аннан меңнәрчә крәстиян Рус Бизнәсенә агыла. Җирле хакимиятнең «Нигезләмә»не аңлатырга тырышулары, крәстияннәрне С.ны тыңламаска, өйләренә таралырга өндәүләре нәтиҗә бирми. 12 апрельдә Рус Бизнәсенә Тарутин полкының граф А.С.Апраксин җитәкчелегендәге 2 ротасы килә. Җыелган крәстияннәргә төбәп ут ачалар. С. кулга алына һәм 19 апрельдә хәрби-кыр мәхкәмәсе нигезендә Рус Бизнәсе авылы читендә атып үтерелә. 1925 тә Антон Петров истәлегенә Рус Бизнәсе авылы *Антоновка* дип үзгәртелә; авыл үзәгендә С.ка һәйкәл куела (1986).

*Әд.:* В у л ь ф с о н Г.Н. Жаждали воли. К., 1986.

**СИ́ДОРОВ** Артём Георгиевич (13.7.1975, Казан), хакимият эшлеклесе. Пенза югары хәрби артиллерия инженерлары уч-щесен (1997), Казан ун-тын (2001) тәмамлый. 1997–2001 еллардан РФ Оборона министрлыгының хәрби вәкиллегендә (Казан) әйдәп баручы инженер ярдәмчесе. 2001–02 дә ТР Эчке эшләр министрлыгы Штабы инспекторы. 2002–06 да ТР Эчке эшләр министрлыгының Әйләнә-тирәне саклау өлкәсендәге хокук бозулар б-н көрәш идарәсе штабы башлыгы. 2006–07 дә ТР Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында эшләр башкаручы. 2007–08 дә ТР Президенты Аппаратының Терр-яләр б-н эшләү идарәсендә баш киңәшче, 2008–10 да идарә башлыгы урынбасары. 2010 нан ТРның экология һәм табигый ресурслар министры. Медальләр б-н бүләкләнә.

**СИ́ДОРОВ** Борис Васильевич (11.7.1941, Ростов өлкәсенең Целина р-ны Надежда станицасы), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1998), проф. (1999). Казан ун-тын тәмамлый (1965). 1965–70 елларда Мордва АССРның Эчке эшләр министрлыгында тикшерүче, тикшерү бүлеге башлыгы булып эшли. 1973 тән Казан ун-тында: криминология лаб-ясендә (1975 кә кадәр), җинаять хокукы кафедрасында (1975 тән). Хезмәтләре җинаять хокукына, аффект хәлендә кылынган гамәлләрне анализлау мәсьәләләренә, үз-үзеңне саклауга һәм җаваплылык дәрәҗәсен төшерүгә яисә кылынган эшнең җинаять итеп каралмавына бәйле шартларны тикшерүгә, криминаль виктимологиягә, җинаять җаваплылыгын, коррупцион һәм вазифаи җинаятьчелекне өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Аффект: его уголовно-правовое и криминологическое значение. К., 1978; Уголовно-правовые гарантии правомерного, социально-полезного поведения. К., 1992; Поведение потерпевших от преступления и уголовная ответственность. К.-Елабуга, 1998.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**СИ́ДОРОВ** Владимир Васильевич (1.12.1932, Казан — 5.6.2012, шунда ук), радиофизик, физика-матем. фән. д-ры (1985), проф. (1986), ТРның һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1996, 2004), Казан ун-тының атказ. профессоры (2007). 1955 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, Проблемалы радиоастрономия лаб-ясенең фәнни җитәкчесе (1964 тән), бер үк вакытта радиоастрономия кафедрасында (1965 тән); радиофизика каф. мөдире (1982–98), шул ук кафедраның профессоры (1998 дән). Хезмәтләре метеор күренешләрен һәм аларның кул-

ланышын тәҗрибәдә тикшерүгә карый. С. вакытны наносекундлар төгәллеге б-н синхронлаштыру алымнарын нигезли һәм үстерә, метеор матдәсе агымына радиолокацион томографик анализ һәм радиодулкыннарның метеорлы таралу шартларын фаразлау алымнарын эшли һәм куллана. Уйлап табуга 20 авторлык таныклыгы бар. РФА Гыйльми советының «Радиодулкыннарның метеорлы таралуы» (1975 тән) һәм РФА Милли ком-тының «Метеорлар» (1993 тән) секцияләре рәисе. 1966 дан «Метеорное распространение радиоволн» еллык фәнни хезмәтләр җыентыгы редакторы (Казан). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Распространение радиоволн на коротких метеорных радиолиниях // Изв. вузов. Радиофизика. 1997. Т. 40, № 6 (автордаш); Спектры долгопериодных вариаций полусуточного прилива и преобладающего ветра на высотах верхней мезосферы — нижней термосферы // Геомагнетизм и аэрономия. 2001. Т. 41, № 6 (автордаш); Метод решения задачи определения координат радиантов метеорных потоков по угломерным данным метеорного радара // Астрон. вестн. 2003. Т. 37, № 3 (автордаш).

**СИ́ДОРОВ** Владимир Павлович (19.5.1939, Липецк өлкәсенең Усмань ш.), компрессорлар төзүче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005), ТРның атказ. машина төзүчесе (2000). 1972 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый. 1961–2006 да компрессорлар төзү буенча махсус КБда (хәзер «НИИтурбокомпрессор»), үзәктән куулы компрессор корпуслары бүлеге башлыгы (1981 дән). С. җитәкчелегендә төрле сәнәгать тармаклары өчен үзәктән куулы компрессорлар һәм кудыру җайланмалары эшләнә. Дәүләт бүләге газ күчерү агрегатлары кудыргычларының югары күрсәткечле алмаш частьларын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сменные проточные части для нагнетателей природного газа // Газотурбинные технологии. 1999. Июнь–авг. (автордаш); Повышение степени сжатия сменной проточной части ГПА-16 // Хим. и нефтегазовое оборудование. 2002. № 8 (автордаш).

*Әд.:* Неразрывность науки и практики — путь к прогрессу // Респ. Татарстан. 2005. 10 дек.

**СИ́ДОРОВ** Игорь Николаевич (13.1.1955, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (2000). 1978 елда Мәскәү физика-техника ин-тын тәмамлый. 1981 дән Казан авиация ин-тында, 1984 тән Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан), 1988 дән Казан техник ун-тында, теоретик һәм гамәли механика каф. мөдире (2003 тән). Хезмәтләре деформацияләнгән каты җисем механикасына һәм матем. модельләштерүгә карый. С. өч үлчәнешле җисемнәрнең тотрыксыз термосыгылмалылыгы статикасы һәм катлаулы геометрияле сүрүләр мәсьәләләрен чишү өчен чик элементлар алымын үстерә. Композит материаллардан төзелгән конструкция элементларын чыдамлылыкка сынау хисапларын эшли. Турбоагрегат вал-үткәргечләренең вибрация халәтен модельләштерә һәм аларда вибрацияне киметү алымнарын эшли.

Х е з м.: О постановках задачи непрерывного наращивания упругих тел // Докл. АН СССР. 1990. Т. 314, № 4 (автордаш); Задача определения остаточных технологических напряжений и перемещений в трёхслойных элементах из композитных материалов, получаемых силовой намоткой // Механика композитных материалов. 1991. № 1 (автордаш); Построение граничных интегральных уравнений различных вариантов теории оболочек сложной геометрии // Изв. РАН. Механика твёрдого тела. 1997. № 4 (автордаш).

**СИ́ДОРОВ** Николай Емельянович (27.10.1898, Казан губ., Зөя өязе Воробьёвка а. — 21.9.1984, Казан), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (1940), проф. (1940), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1968). В.С.Груздев шәкерте. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1925), Казан шәһәрендәге 4 нче хастаханәдә эшли, бер үк вакытта Казан ГИДУВының акушерлык-гинекол. клиникасында ординатор. 1930 елдан Казан ГИДУВының 1 нче акушерлык һәм гинекол. кафедрасында, 1948–73 тә каф. мөдире. Бөек Ватан сугышы елларында Волхов фронты госпитальләренең баш гинекологы (1941–43); 1944 тән Казан эвакогоспитале башлыгы. Хезмәтләре хатын-кызларның җенес органнарындагы ялкынсыну, шеш процесслары-на диагноз кую һәм авыруларны дәвалауга, балага уза алмаучы хатын-кызларның җенес органнары эшчәнлегенә, бала табу процессында авыртусызландыруга карый. Кызыл Йолдыз, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О времени появления гонадотропного гормона передней доли гипофиза в эмбриональной жизни человека. К., 1933; Контрастная рентгенография изменений матки после операции кесарева сечения и диагностика неполноценного рубца. К., 1970 (автордаш); Разрывы матки по рубцу после кесарева сечения. К., 1974 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Николай Емельянович Сидоров // Казан. мед. журн. 1985. № 1.

*В.Ф.Богоявленский.*

**СИДОРУ́К** Евгений Александрович (29.9.1950, Горький (хәзер Түбән Новгород) өлкәсенең Сергач ш.), хирург-анестезиолог-реаниматолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004), мед. фән. канд. (2000), ТРның һәм РФнең атказ. табибе (1994, 2003). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), Респ-ка клиник хастаханәсендә хирург булып эшли; 1976 елдан Респ-ка онкология диспансерында. 1977 дән Казан ГИДУВының анестезиология һәм реаниматология кафедрасында, 1979 дан ГИДУВның 2 нче акушерлык-гинекол. клиникасында табиб-анестезиолог-реаниматолог, 1986 дан ТР Эчке эшләр министрлыгы хастаханәсендә. 1988 дән Респ-ка кан салу станциясе баш табибе, бер үк вакытта, 2000 нән, Казан мед. академиясендә трансфузиология курсы мөдире. Хезмәтләре гадәттән тыш хәлләрдә терр. кан салу хезмәтен оештыру һәм идарә итү мәсьәләләренә карый. Дәүләт бүләге донор канын һәм аның компонентларын оптималь шартларда саклауны тәэмин итү максатыннан медицинага ярашлы махсус суыткыч техника эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Уйлап табуга патенты бар.

Х е з м.: Служба крови: Нормативы по труду, ценообразование. М., 2003 (автордаш); Распределение группы крови среди доноров г.Казани // Общественное здоровье и здравоохранение. 2005. № 1/2 (автордаш); Плазмаферез в лечении латентно протекающего синдрома ДВМ у больных бронхиальной астмой // Казан. мед. журн. 2009. № 2.

**СИДУ́ЛОВО-ЕРЫКЛЫ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 23 *км* төньяктарак урнашкан. 2010 елда 152 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1920 ләрдә нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Яңа Әдәм волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 260, 1938 дә — 247, 1949 да — 137, 1958 дә — 252, 1970 тә — 255, 1979 да — 241, 1989 да — 130, 2002 дә — 142 кеше.

**СИЗНЕ́Р** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 28 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Арбор елгасы буенда. 2010 елда 212 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1711 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Сизнер Первого Усада исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, аучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү, чиркәү-приход мәктәбе (1899 да ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 985,9 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Сизнер волостенда, 1921 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1746 да — 92, 1763 тә — 159, 1795 тә — 116 кеше, 1811 дә — 110 ир-ат; 1850 дә — 162, 1859 да — 259, 1884 тә — 293, 1897 дә — 319, 1905 тә — 388, 1920 дә — 440, 1926 да — 471, 1938 дә — 438, 1949 да — 298, 1958 дә — 264, 1970 тә — 308, 1979 да — 258, 1989 да — 197, 2002 дә — 203 кеше.

**СИЗО́В** Борис Алексеевич (28.2.1946, Вологда өлкәсенең Белозёрск ш.), тау инженеры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004), ТРның атказ. нефтьчесе (1996). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1974). Хезмәт эшчәнлеген 1962 елда Петрозаводск мебель комб-тында столяр-җыючы булып башлый. 1969–71 дә Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тының Татарстан кичке ф-тында эшли (Әлмәт ш.). 1970–73 тә, 1976–2007 дә «Татнефть» АҖдә: берләшмәнең үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясенең бораулау бүлегендә өлкән инженер, «Ямашнефть» НГДУында хезмәтне саклау һәм техник куркынычсызлык бүлеге башлыгы, АҖнең хезмәтне саклау һәм сәнәгать куркынычсызлыгы идарәсе башлыгы (1989 дан). 1973–76 да ачык нефть һәм газ фонтаннарының барлыкка килүен алдан кисәтү һәм бетерү буенча Әлмәт хәрбиләштерелгән отряды инженеры. Дәүләт бүләге Татарстанның көнь-

як-көнчыгышында табигатьне саклау чараларын планлаштыру һәм гамәлгә кертү максаты б-н геомәгълүмат системаларын эшләгәне һәм гамәлгә кертүкәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**СИКЕ́З БӘК** (? – ?), Алтын Урда бәге. Азак шәһәре идарәчесе (1349). 1360 елларда Пьяна елгасы төбәгенә качарга мәҗбүр була, шул төбәктәге мордваларны буйсындырып, үз олысын булдыра, кальга төзетә. 1370 еллар тирәсендә, олысын Мамай басып алгач, Мәскәүнең бөек кенәзе Дмитрий Донскойга хезмәткә күчә, христиан динен кабул итә. Рус дворяннары Черкизовлар (Старковлар) нәселенә нигез сала.


*Әд.:* С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Ф ё д о р о в - Д а в ы д о в Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973. *И.Л.Измайлов.*

**СИКЕРТӘ́Н** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кесмәс елгасы буенда. 2010 елда 185 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында На врагу Сикиртан исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез итек-киез җитештерү һәм өс-баш киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, тимерчелек, су тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1415,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 164 ир-ат; 1859 да — 720, 1897 дә — 936, 1908 дә — 1014, 1920 дә — 1019, 1926 да — 703, 1938 дә — 763, 1949 да — 610, 1958 дә — 464, 1970 тә — 368, 1979 да — 279, 1989 да — 203, 2002 дә — 169 кеше.

**СИКИЯ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Сөн елгасының (Агыйдел елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 27,3 *км*, бассейнының мәйданы 192 *км*$^2$. Елга башы Мөслим р-ны Уразмәт Чишмәсе авылыннан көньяк-көнбатыштарак, тамагы Актаныш р-ны Иске Байсар авылының көньяк-көнбатыш читендә. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 75 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. С.нең 5,3 тән 19,4 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,33 *км/км*$^2$. Туеныу катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 75 *мм*, ташу агымы катламы 66 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,06 *м*$^3$*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. С. бассейнында суының гомуми күләме 6,2 млн. *м*$^3$ булган 4 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**СИКИЯ́** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 42 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сикия елгасы буенда. 2010 елда 88 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб. 1735 тән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, С.дә мәчет, мәктәп, су тегермәне эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 2350,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1795 тә — 169 кеше, 1816 да — 94 ир-ат; 1834 тә — 250, 1859 да — 454, 1870 тә — 562, 1897 дә — 661, 1913 тә — 922, 1920 дә — 927, 1926 да — 742, 1938 дә — 710, 1949 да — 435, 1958 дә — 378, 1970 тә — 282, 1979 да — 201, 1989 да — 162, 2002 дә — 126 кеше.

**СИ́КЛЕР** Леон Осипович (1858, С.-Петербург — 1921 яки 1922, Париж), рәссам, коллекционер, сәнгать белгече. Балалык һәм үсмерлек елларын Франциядә уздыра. Париждан ерак түгел колледж тәмамлый (1878), тел һәм әдәбият белемен Бордо шәһәрендә



«Л.О.Сиклер портреты». Рәссам Бальц. Агач. Майлы буяу. 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТР Милли музее.

ала, нәкышь сәнгатен Парижда, рәссам Бугрда үзләштерә. 1870 еллар ахырында Казанга килә. Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә (1893 тән), Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында, реаль уч-щеда (1900 дән), Казан ун-тында (1910 еллар башыннан) француз теле һәм әдәбияты укыта. Казан нәфис сәнгать сөючеләр җәмгыяте әгъзасы (1895). 1919 да Франциягә китә.

Күбесенчә реалистик юнәлештә иҗат итә. Портрет («Мех якалы яшел күлмәк кигән хатын-кыз портреты», 1886; «Ханым портреты», 1880 еллар; «Казан антиквары Якуб Ишмиев портреты», 1890 еллар; «Яшь татар хатын-кызы», 1896), пейзаж (Казанның тирә-юне сурәтләнгән этюдлар) жанрларында эшли; китапларга иллюстрацияләр ясый.



Л.О. С и к л е р. «Казан антиквары Якуб Ишмиев портреты». Агач. Майлы буяу. 1890 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

С. тарафыннан француз телендәге рус әкиятләренә иллюстрация буларак башкарылган «Шәһәр урамы» гравюрасының эскизы (тушь) аның 16 йөз ахыры — 17 йөз башы рус архит-расын һәм көнкүрешен яхшы белүен күрсәтә.

Казанга килүенең беренче елларыннан С. татарлар һәм башка Идел буе халыкларының матди мәдәнияте предметларыннан этнографик коллекция җыя башлый (5 меңнән артык саклау берәмлеге). Тупланмаларының аеруча кыйммәтле һәм уникаль өлеше Казан татарларының гамәли-бизәлеш сәнгате әсәрләре була: ир-атлар һәм хатын-кызларның өс-баш, аяк киемнәре, көнкүреш әйберләре, зәркән эшләнмәләр. С. тупланмаларыннан оештырылган беренче күргәзмә (татарларның борынгы өс киемнәре, сөлгеләр, бизәнү әйберләре, мөһерләр, Коръән һәм догалык савытлары һ.б.) 1912 дә Казан ун-тында уздырыла. Җирле матбугатта күргәзмәгә югары бәя бирелә. Ул арада, әлеге тупланмалар галимнәр һәм коллекционерлар арасында зур кызыксыну уята, С.-Петербург, Мәскәү, Германия, Швеция, Финляндия, Төркия галимнәре һәм музей коллекционерлары аларны сатып алырга теләк белдерә. 1919 да, тупланмаларның сакланышын кайгыртып, рәссам аларны Идел буе бөтенроссия музейлар һәм борынгы истәлекләрне саклау эшләре коллегиясенә сата, тупланманың бер өлеше, Казанга кайтару шарты б-н, Мәскәүгә җибәрелә. Ләкин коллекциянең күпчелек өлеше (Болгар, Биләр табылдыклары, рус, чуаш һәм мари этнографик материаллары) Хельсинкидагы Финляндия Милли музеенда пәйда була. ТАССР Үзәкләштерелгән музее хезмәткәре Б.Ф.Адлерның актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә 1920 дә Казанга 1700 данә тарихи ядкәр кайтарыла (ТР Милли музеенда һәм ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда

сакланалар). А.Ф.*Лихачёв* сәнгать коллекциясенең кыскача күрсәткечен төзүче-автор буларак, С. аны системага сала һәм өлешчә атрибутлаштыра.

1890 еллар ахырында — 1900 еллар башында Казанда узган сәнгать һәм тарих күргәзмәләрендә катнаша. Әсәрләре ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.

Х е з м.: Краткий указатель картин коллекции А.Ф.Лихачёва в Казанском городском музее. К., 1895; Краткий указатель художественной этнографическо-археологической выставки, собранной Л.О.Сиклером. К., 1912.

*Әд.:* Каталог Первой выставки картин и этюдов местных и иногородних художников в помещении Казанской художественной школы. К., 1896; А д л е р Б.Ф. Коллекция Сиклера // Казан. музейный вестн. 1922. № 2; Русское искусство XVII — начала XX веков. Живопись: Каталог. К., 2005.

*И.Ф.Лобашева.*

**СИКСӘ́Н АЛТЫНЧЫ́ МО́ТОУКЧЫ ДИВИ́ЗИЯ**, ТАССР ЮС Президиумы исемендә, 1930 елларда 1 нче Казан дивизиясе җирлегендә оештырыла. Дивизия командирлары: полковник Ю.В.Новосельский, полковник М.А.Зашибалов. Дивизия 1939–40 еллардагы совет-фин сугышында катнаша. Кызыл Байрак ордены б-н бүләкләнә, 13 хәрбигә Сов. Союзы Герое исеме бирелә, 342 се орденнар һәм медальләр б-н бүләкләнә. 1940 ның язында дивизия ТАССРга, даими урнашкан урынына кайта, 1940 ның ахырында Белоруссиягә күчерелә. 1941 нең 22 июнендә Польша б-н чиктәш Цехановец шәһәре тирәсендә немец-фашист гаскәрләре һөҗүменә каршы тора һәм чик буе сакчылары б-н берлектә аларны СССР чикләреннән алып ташлый. Соңрак командование боерыгы б-н Гродно, Волковыск, Брест сызыгына чигенә башлый. Чолганышта кала. Дивизиянең исән калган өлеше (3 меңгә якын кеше) Гомель шәһәре тирәсендә чолганыштан чыга. Шәхси составның күпчелегe башка частьларны яңадан оештыру яки тулыландыру өчен җибәрелә.

*В.Ф.Телишев.*

**«СИКСӘ́Н ИКЕЛӘ́Р ХАТЫ́»**, татар теленең латин хәрефле язуга (яңалифкә) күчүен ашыктыру ярамаганлыгы турында язылган хат; 1927 елда И.В.Сталинга һәм ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты җитәкчелегенә җибәрелә. Татар зыялыларының күренекле вәкилләре — табибләр, журналистлар, инженерлар, педагоглар, язучылар, рәссамнар (барысы да партиясез) тарафыннан кул куела. Аларны матбугатта һәм җыелышларда иҗтимагый-сәяси эзәрлекләү кампаниясе башлана. Нәтиҗәдә, хат авторларының күпчелеге үз фикерләреннән баш тарта һәм шул турыда матбугатта язып чыга. ВКП(б) өлкә ком-тының «С.и.х.»на җавап итеп кабул ителгән 4 нче пленумы карарында төрки алфавитлар мәсьәләсенең хәл ителгән дип саналуы сәбәпле бу уңайдан берninди дә каршылыклы фикерләр булырга тиеш түгеллеге, мондый мөрәҗәгатьнең гамәлләре б-н ВКП(б)га каршы юнәлдерелгән милли-буржуаз элементларның үз көчендә булуын раслаучы күрсәткеч икәнлеге әйтелә. 1930 елларда «С.и.х.»нда катнашу күп очракта «халык дошманары»ның контрреволюцион һәм совет хакимиятенә каршы оештырган акцияләре буларак бәяләнә; хатка кул куючыларның күбесе репрессияләнә.

*Әд.:* Т а г и р о в И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999.

*Б.Ф.Солтанбәков.*

**СИЛА́НТЬЕВ** Владимир Владимирович (14.8.1967, Ленинград), геолог-палеонтолог, геол.-минерал. фән. канд. (1995). Казан ун-тын тәмамлый (1989), шунда ук эшли, стратиграфия һәм палеонтология каф. мөдире (1997 дән), бер үк вакытта геол. музее директоры (2006 дан). Хезмәтләре геол. мираска һәм Пермь утырмаларына карый. С. диңгезләрдә яшәмәүче ике кабырчыклы моллюскларның яңа төрләрен ачыклый, Россиянең Көнчыгыш Европа өлешендә стратотипларны һәм терәк горизонтларны билгели. «Казан Кремле» музей-саклаулыгында Татарстанның табигыять тарихы музеен оештыру эшләренең фәнни җитәкчесе (2006–09).

Х е з м.: Стратиграфический разрез татарского яруса на р.Вятке. М., 2001 (автордаш); Геология для всех. К., 2011 (автордаш); Геологические памятники природы Республики Татарстан. К., 2013 (автордаш);

**СИ́ЛКИН** Николай Иванович (16.12.1945, Казан — 1.9.2011, шунда ук), физик, физика-матем. фән. д-ры (2009), проф. (2010). 1969 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 2010 нан квант электроникасы һәм радиоспектроскопия каф. профессоры. Хезмәтләре магнит күренешләре физикасына, квант электроникасына, мед. физикасына карый.

Х е з м.: ЭПР примесных центров $Pb^{2+}$ в кристаллах гомологического ряда флюорита // Физика твёрдого тела. 1976. Т. 18, № 10 (автордаш); Активные среды для перестраиваемых лазеров на основе хромосодержащих фторидов // Изв. АН СССР. Сер. Физика. 1990. Т. 54, № 6 (автордаш); Влияние излучения гелий-неонового лазера на регенерацию вкусовых точек языка крысы // Лазерная медицина. 2003. Т. 7, вып. 2.

**СИЛЛА́БИК ШИГЫ́РЬ ТӨЗЕЛЕШЕ́** (грек. syllabē — иҗек), тезмә юлларда иҗекләрнең бертигез санда кабатланып килүенә нигезләнгән шигырь төзелеше системасы. Мондый шигырь системасы сүз басымнары чагыштырмача йомшак һәм тотрыклы булган телләрдә, мәс., французларда һәм төрки халыклар поэзиясендә кулланыла. Басымлы һәм басымсыз иҗекләр бер-берсеннән нык аерылмыйлар, шуңа күрә алар шигырь юлларында ирекле рәвештә урнашалар. Силлабик ритм системасы иҗекләр санына нигезләнә. Әлеге төр шигырь төзелешендә изосиллабизм, яки тигез иҗеклелек принцибы юлларның бертигез озынлыкта килүендә генә гәүдәләнеп калмый, ә аларның эчке төзелешенә дә үтеп керә һәм ритмик буыннарны да үзенә буйсындыра. Икенче төрле әйткәндә, һәр шигырь юлы цезуралар-тураклар ярдәмендә тагын да ваграк кисәкләргә — ритмик буыннарга бүленә. Соңгылар тегe яки бу зурлыкта гына килүләре һәм үзара чиратлашулары б-н үзенчәлекле метрик дулкын һәм төрле ритмик үлчәмнәр барлыкка китерә. Силлабик шигырь төзелеше — татар халык лирикасында һәм язма поэзиясендә элек-электән кулланылып килгән төп шигырь системасы. Гасырлар дәвамында бездә силлабик шигырьнең күп төрле үлчәмнәре формалаша. Шуларның иң киң кулланылганнары — 7–7, 8–7, 11–11 һәм 10–9 иҗекле үлчәмнәр.

Бу дөньяда | иң сөекле (8)
Ике чәчәк | бар икән; (7)
Берсе яшьлек, | икенчесе (8)
Өзелеп сөйгән | яр икән (7)
(Халык җыры)
Җыр өйрәтте | мине | хор яшәргә (10)
Һәм үләргә | кыю | ир булып; (9)
Гомрем минем | моңлы | бер җыр иде, (10)
Үлемем дә | яңрар | җыр булып (9)
(М.Җәлил)

Силлабик шигырьләр арасында катнаш үлчәмлеләре дә очрый. Мондый шигырьдә тегe яки бу озынлыктагы юллар строфа рәвешендәге төркемнәргә берләшеп, ягъни төркем-төркем булып чиратлашып киләләр. Мәсәлән, 5–5–5, 7–7–7, 4–4, 7–7; яки 4–4–4, 8–8–8, 4–8, 6–6–4. Юллар озынлыгының үзгәреп торуы ягыннан катнаш үлчәмле шигырь *ирекле шигырьне* хәтерләтсә дә, ул, асылда, ирекле шигырь түгел. Төрки халыкларда силлабик ритмлы шигырьне «бармак шигыре» дип тә йөртәләр. Шулай ук кайбер әдәбиятчылар «саниҗек шигырь» дигән синонимик атама да кулланалар.

*Әд.:* К у р б а т о в Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. К., 2002; Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. К., 2007; Х а м р а е в М. Основы тюркского стихосложения. А.-А., 1964.

*М.Х.Бакиров.*

**СИ́ЛОС** (исп. silos), сусыл терлек азыгы, әчетеп яисә үсемлекләрнең яшел массасын һава кертмичә һәм сөтле әчеткеч нигезендә консервлап әзерләнә. 1930–50 елларда Татарстанда С., нигездә, төрле үләннәрдән әзерләнә, 1950 еллардан югары сыйфатлы С. әзерләү өчен җиңел силослана торган, шикәргә бай, әчү процессында сөт кислотасы, консервлау өчен кирәкле яшел масса барлыкка китерергә сәләтле силос культуралары: кукуруз, көнбагыш, рапс, күп компонентлы борчаклы-солылы, викалы-солылы катнашмалар, бүлбе-тамыразыклар үстерелә. Кайбер хуҗалыкларда шикәр соргосы, судан үләне, терлек азыгы һәм яшелчә культуралары сабаклары, топинамбурның җир өстендә үскән массасы кушылмалары кулланыла. Силос культураларын силослау өчен иң уңай үсеш фазасы сайлана: кукурузны — сөтле-балавызлы, балавызлы өлгереш вакытында, көнбагышны — чәчәк ата башлаганда, борчаклы-солылы, викалы-солылы азык катнашмаларын — кузаклана башлаганда, табигый терлек азыгы үләннәрен — кыяклы үләннәр башаклана башлаганда чәчелгән (кузаклы, кыяклы) һәм күпьеллык үләннәрне — бөреләнә башлаганнан, чәчәк ата башлаганчы, табигый һәм чәчелгән үләннәрне — үсүенә карап, тамыразыкларның сабакларын — уңышларын җыярга 2–3 тәүлек калгач, көзгә арышны бөреләнә башлаганда җыялар.

С. туклыклылыгы буенча силослана торган массага якын. 100 *кг* кукуруз С.ында якынча 20 азык берәмлеге һәм 1,4 *кг* үзләштерелә торган протеин, көнбагыш С.ында якынча

16 азык берәмлеге һәм 1,4 *кг* үзләштерелә торган протеин, люцерна С.ында 18 азык берәмлеге һәм 2,9 *кг* үзләштерелә торган протеин була. С.та каротин һәм С витамины саклана, суда эри торган шикәрләр бар; органик к-талар: сөт (2% ка кадәр), серкә (0,6% ка кадәр), С.ның кайбер төрләрендә — пропион, валериан к-талары бар, силослау технологиясен дөрес үтәмәгәндә һәм дөрес сакламаганда май к-тасы барлыкка килә. С.ны барлык а.х. терлекләренә, нигездә, кыш көне ашаталар. Туклыклылыгы буенча С. мөгезле эре терлек рационының 50% ын, дуңгызлар рационының 20% ын тәшкил итә. Татарстан терлекчелегендә С.ны еллык куллану 1–1,4 млн. *т* тәшкил итә.

*Әд.:* З а ф р е н С.Я. Как приготовить хороший силос. М., 1970; З а р и п о в а Л.П. Ресурсы кормового белка. К., 1985; Рациональные способы приготовления кормов к скармливанию. К., 1991; М а л и к о в М.М. Система кормопроизводства в Республике Татарстан. К., 2002.

**СИЛЬВЕ́СТР** (Холмский) (якынча 1650 ел, кайбер мәгълүматлар буенча, Псков җиреннән — 31.5.1735, Выборг ш.), дин эшлеклесе. Литва яки Белоруссиядәге борадәрлек мәктәпләренең берсен тәмамлый. 1690 елларда Новгород архиерей йорты казначее. Түбән Новгородтагы Деревяницкий (1700–04) һәм Юрьев (1704) монастырьлары архимандриты. 1704 елдан Троица-Сергий лаврасы архимандриты. 1708 дән — Түбән Новгород һәм Алатырь, 1719 дан — Смоленск, 1720 дән Тверь митрополиты, 1724 тән Рязань, 1725–32 дә (гамәлдә 1731 гә кадәр) Казан епископы, 1727 дән митрополит. 1731 дә, дәүләтнең чиркәү сәясәте һәм җирле түрәләрнең башбаштаклыгы б-н килешмәве нәтиҗәсендә, башта Түбән Новгородтагы Благовещение монастырена, аннары С.-Петербургның Александр Невский лаврасына, 1732 дә Псков епархиясенең Крыпецкий монастырена сөрелә. 1733 тә руханилык дәрәҗәсеннән мәхрүм ителә һәм Выборг крепостена ябыла. Казан епископы булып хезмәт иткән чорда *Казан архиерей славян-латин мәктәбе*нә зур игътибар бирә, аны финанслауны арттыра, укыту дәрәҗәсен күтәрә.

*Әд.:* З н а м е н с к и й П.В. Сильвестр, митрополит Казанский // Православное обозрение. 1878. № 4–6; Л и п а к о в Е.В. Архипастыри Казанские. 1555–2007. К., 2007.

**СИМАШЁВ** Фёдор Петрович (13.3.1945, Зәй р-ны Югары Баграж а. — 19.12.1997, Зәй ш.), спортчы (чаңгыда узышу), СССРның атказ. спорт остасы (1970), ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (1994). Н.К.Крупская исем. Мәскәү өлкә пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1973). «Динамо» (Мәскәү) физкультура спорт җәмгыятендә тәрбияләнә, тренеры — В.Бучин. СССР чемпионы (1968, 15 *км*, 4×10 *км*; 1969, 30 *км*, 4×10 *км*; 1970, 4×10 *км*; 1971, 30 *км*; 1972, 4×10 *км*; 1973, 30 *км*, 4×10 *км*; 1974, 50 *км*; 1975, 1976, 4×10 *км*), дөнья (1970, 1972, 4×10 *км*), Олимпия уеннары (1972, 4×10 *км*) чемпионы. СССР (1968, 50 *км*; 1969, 70 *км*; 1970, 30 *км*; 1971, 50 *км*; 1972, 1973, 15 *км*; 1974, 15, 30, 70 *км*), дөнья (1972, 15 *км*; 1974, 4×10 *км*) чемпионатларында, Олимпия уеннарында (1972, 15 *км*) көмеш медаль ала; СССР (1969, 1972, 50 *км*; 1974, 4×10 *км*; 1975, 1976, 50 *км*), дөнья (1970, 15 *км*) чемпионатларында бронза медаль ала. 1966–91 дә Мәскәүдә, 1978–89 да «Динамо» Мәскәү өлкә советында өлкән тренер, 1989–91 дә «Динамо» үзәк советында баш тренер. Бер үк вакытта Зәй шәһәрендә: 1966–91 дә тау чаңгысы буенча инструктор, 1991–93 тә автоагрегатлар з-дында спорт һәм физкультура-сәламәтләндерү эше буенча директор ярдәмчесе, 1993–95 тә соц.-көнкүреш бүлегенең бюро башлыгы; 1995 тән «Ялта-Зәй» спорт-сәламәтләндерү идарәсендә физкультура һәм спорт буенча әйдәп баручы белгеч; 1996 дан автоагрегатлар з-дында физкультура һәм спорт буенча әйдәп баручы белгеч. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Зәйдә 1971 дән С. призына традицион ярышлар, 1997 дән С. истәлегенә ТРның иң көчле чаңгычылары ярышлары уздырыла.

**СИМӘ́К** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 24 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Мөшеге елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 269 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1701 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлек асрау, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, С.тә мәчет, мәктәп, су тегермәне эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1531,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1816 да — 82 ир-ат; 1859 да — 306, 1870 тә — 340, 1897 дә — 543, 1920 дә — 734, 1926 да — 655, 1938 дә — 743, 1949 да — 441, 1958 дә — 377, 1970 тә — 353, 1979 да — 385, 1989 да — 315, 2002 дә — 269 кеше.

**СИМӘКИ́** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 5 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Бәрле елгасы буенда. 2010 елда 68 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 60%, руслар — 35%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, җиләк-җимеш үстерү. 17 йөздә нигез салына. Халкы башта Зөя Успение Богородица монастырена карый, 1763 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.дә су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 499 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Кошман волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән — Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 99 ир-ат; 1859 да — 304, 1897 дә — 476, 1908 дә — 552, 1920 дә — 457, 1926 да — 411, 1938 дә — 341, 1949 да — 228, 1958 дә — 188, 1970 тә — 171, 1979 да — 124, 1989 да — 183, 2002 дә — 267 кеше.

**СИМБИ́РИН** Ефим Александрович (22.11.1923, Казан — 1.7.2000, шунда ук), нәкышьче, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1974), ТАССРның халык рәссамы (1981). Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый. 1947–71 һәм 1975–83 елларда Татарстан Сәнгать фондында эшли: рәис (1975–80), рәис



Е.А.С и м б и р и н. «КамАЗ төзүче Хәян Әюпова портреты». 1972. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

урынбасары (1980 нән). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1971). Рәссамнар династиясе вәкиле: әтисе А.Ф.Симбирин (1898–1959) нәкышьче була, Казандагы сәнгать күргәзмәләрендә катнаша; улы, А.Е.Симбирин (1950 дә туган) — сынчы (керәч паннолар авторы), бизәүче.

Портрет жанры осталарының берсе буларак, С. пейзажга һәм тематик картинага мөрәҗәгать итә. 1960 еллар башында тракторчылар З.Нуретдинов (1960), К.Вәлишин (1961), сыер савучы Р.Сабирова (1963) портретларын иҗат итә. Соңрак натурадан төшерелгән портретлардан зур форматлы портрет-картиналарга күчә: образларның хисси киеренкелеге, контрастлы колориты б-н аерылып торган «Идел ветераны» (1965–67), ике тапкыр Соц. Хезмәт Герое А.Улесов



Е.А.С и м б и р и н. «Г.Тукай». 1976. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

(1973–74), Соц. Хезмәт Герое С.Нәфыйкова (1969) портретлары. Ярты гасырлык иҗат эшчәнлегендә С. замандашлары портретларының зур галереясын барлыкка китерә: Татарстанның авыл хезмәтчәннәре, эшчеләр, төзүчеләр, интеллигенция вәкилләре (проф. А.Я.Гордягин, 1968; проф. Л.М.Миропольский, 1975). Иң әһәмиятлеләре «КамАЗ төзүчеләр» тематик сериясе: Х.Эюпова (1972), М.Хисмәтуллин, М.Коваленко, А.Баязитов (барысы да — 1973), М.Ибәтуллин (1978–79) портретлары. С. тарихи портрет жанры үсешенә зур өлеш кертә: М.Җәлил (1975), Р.Вагнер, Г.Тукай (икесе дә — 1976), С.Сәйдәшев (1978), К.Маркс, В.И.Ленин (икесе дә — 1979), Ш.Камал, Ф.Әмирхан (икесе дә — 1982) портретлары.

Респ-ка (1948 дән), зона — «Зур Идел» (1964, 1967, 1969, 1974, 1980, 1991), бөтенроссия — «РСФСРның 10 автономияле республикасы» (Казан, 1950), «РСФСРның 16 автономияле республикасы» (Мәскәү, 1971) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда (1973, 1983), Чаллыда (1974) уздырыла.

Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, А.М.Горькийның Казандагы әдәби-мемориаль музеенда, Казан ун-тының тарих музеенда, Әлмәт шәһәрендәге Картиналар галереясында, Арча р-нының Яңа Кырлай авылындагы Г.Тукай музей-комплексында саклана.

Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Я х л и е л ь Б. Симбирин Ефим Александрович. К., 1975; Ч е р в о н н а я С.М. Искусство Советской Татарии. М., 1984.

*М.С.Ильина.*

**СИМГӘ́** елгасы, Идел алдында, Коры Үләмә елгасының (Зөя елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 11 *км*, бассейнының мәйданы 54,7 *км*$^2$. Идел буе калкулыгы буйлап Кама Тамагы р-нында ага. Елга башы Красновидово (Каратун) авылыннан 3 *км* көньяктарак, тамагы Кече Бортас авылыннан 27 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 90 *м*. Су җыелу мәйданында урман үсемлекләре үсми диярлек. С.нең 0,8 дән 6,6 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,37 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Җәен елга урыны-урыны б-н кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 124 *мм*, ташу агымы катламы 120 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,008 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**СИМЕНЕ́ЕВО** (Би) авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 26 *км* көньяктарак, Инеш елгасы (Зәйнең сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 16 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Зирекле, Семёновка исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, олаучылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, су тегермәне эшли. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Сухарев волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1920 дә — 151, 1938 дә — 128, 1949 да — 153, 1958 дә — 118, 1979 да — 132, 1989 да — 46, 2002 дә — 23 кеше.

**СИМЕО́Н БИКБУЛА́ТОВИЧ** (Саин Булат хан) (? — 5.1.1616, Мәскәү), татар солтаны, Касыйм ханы (1570 тән соң — 1573 кә кадәр). Бикбулат ханның улы, *Әхмәд хан* оныгының улы. 1558 елда атасы б-н бергәләп Нугай Урдасыннан патша Иван IV кә хезмәткә чыгып китә. 1560 еллар ахырында *Касыйм ханлыгы* тәхетенә утыртыла. 1571–73 тә, Ливон сугышы вакытында (1558–83) Орешек, Вейсенштейн (хәзер Пайде ш.), Колывань (хәзер Таллин) кальгалары янындагы яуларда катнаша, алдынгы һәм каравыл полклары җитәкчесе; башка воеводалар б-н бергә Коловери шәһәре янындагы сугышта тар-мар итеЛә. Патша таләбе б-н чукына һәм Симеон исемен ала (1573). Чукынганнан соң бояр И.Ф.Мстиславскийның кызы Анастасиягә өйләнә. 1575 тә Иван IV С.Б.ны «Русьның бөек кенәзе» дип атап, вакытлыча үз урынына идарәче итеп калдыра. Тарихчылар бу вакыйганы патшаның башбаштаклыгы (Н.И.Костомаров, Д.И.Иловайский), земство башлыгын алмаштыру максаты б-н оештырылган сәяси уен (С.М.Соловьёв, К.Н.Бестужев-Рюмин) һәм опричнинаның бер эпизоды һәм аның нәтиҗәләре (С.М.Середонин, С.Ф.Платонов, В.Б.Кобрин, Б.Н.Флоря) дип аңлаталар. Дәүләтнең чын идарәчесе — Иван IV була (мәс., хакимиятнең кем кулында икәнлеген күрсәтер өчен, ул чит ил вәкилләрен кабул итә), ә С.Б. аның әмерләрен үти. 1576 да Иван IV тәхетне «кире кайтара», С.Б. Торжок шәһәренә үз биләмәләренә җибәрелә. 1576–85 тә С.Б. — Тверьнең бөек кенәзе. Бөек кенәз сарае (Мәскәүдәге патша сараеның кечерәйтелгән күчермәсе), приказлар, боярлар һәм стольниклар, Тверьдә сарай, Кушалино авылында резиденция, 13,5 мең дис. чәчү җирләре хуҗасы була. 1577–82 дә Ливония һәм Польшага каршы хәрби хәрәкәтләрдә катнаша. С.Б.ның каенатасы, И.Ф.Мстиславский, Иван IV үлгәннән соң (1584) һәм тәхеткә Фёдор Иванович утырганнан соң, Борис Годунов б-н көрәш нәтиҗәсендә титулы һәм утарларыннан мәхрүм ителә, үзе Кушалино авылына җибәрелә. Патша улы Дмитрий һәлак булып, патша Фёдор Иванович үлгәннән соң, Романов һәм Бельский җитәкчелегендәге бер төркем боярлар С.Б.ны тәхеткә утыртырга телиләр. 1598 дә Борис Годунов боярларны С.Б.ны яклаудан баш тарттырып ант иттерә. 16–17 йөзләр чигендә Годунов боерыгы б-н С.Б. сукырайтыла; улы Иван җәзалап үтерелә. Ялган Дмитрий I Мәскәү тәхетенә утыргач, С.Б. мәҗбүри рәвештә Кирилл-Белоозеро монастырена җибәрелә һәм Стефан исемендә монахлык кабул итә (1606). Ялган Дмитрий I тәхеттән төшерелгәч, патша Василий Шуйский боерыгы б-н Соловки монастырена җибәрелә (1606). 1612 дә Кирилл-Белозеро монастырена кире кайтарыла. Тәхеткә Михаил Романов утыргач, Мәскәүгә кайта. Симон монастырендә җирләнә (кабере сакланмаган).

Чыг.: Полное собрание русских летописей. СПб., 1906. Т. 13; Г о р с е й Дж. Записки о России, XVI — начало XVII в. М., 1990; Проезжая по Московии: Россия XVI–XVII вв. глазами дипломатов. М., 1991.

*Әд.:* В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследования о Касимовских царях и царевичах. СПб., 1864. Ч. 2; Л и л е е в Н.В. Симеон Бекбулатович, хан Касимовский, великий князь всея Руси, впоследствии великий князь Тверской. 1567–1616. Тверь, 1891; З и м и н А.А. Иван Грозный и Симеон Бекбулатович // Из истории Татарии. К., 1970.

*И.Л.Измайлов.*

**СИМЕ́Т** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Ашыт елгасының (Иләт елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 22,7 *км*, бассейнының мәйданы 155,7 *км*$^2$. Елга башы Арча р-ны Симетбаш авылында, тамагы Әтнә р-ны Дусым авылыннан 2 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 102 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. С.нең 1 дән 4,7 *км* га кадәр



Симет елгасы.

озынлыктагы 10 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,3 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 162 *мм*, ташу агымы катламы 140 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче унконлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,115 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. С. бассейнында суының гомуми күләме 1 млн. *м*$^3$ булган 4 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**СИМЕТБА́Ш** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 28 *км* төньяктарак, Симет елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 143 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киндер сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.та мәчет, мәктәп, җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 751,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Яңа Кишет волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 25 ир-ат; 1859 да — 428, 1897 дә — 488, 1908 дә — 438, 1920 һәм 1926 да — 371 әр, 1938 дә — 422, 1949 да — 305, 1958 дә — 249, 1970 тә — 242, 1979 да — 193, 1989 да — 125, 2002 дә — 147 кеше.

**СИМО́ЛИН** Александр Александрович (10.10.1879, Казан — 1920), барон, хокук белгече, гражданнар хокукы һәм мәхкәмә эше д-ры (1916), Конституцион-демократик партиянең Казан оешмасы җитәкчеләренең берсе. Г.Ф.*Шершеневич* шәкерте. 1898 елда Казандагы Икенче ир балалар гимназиясен тәмамлый. Казан ун-тын тәмамлагач (1902), шунда ук эшли, 1905 тән приват-доцент, 1916 дан гражданнар хокукы һәм мәхкәмә эше каф. профессоры, бер үк вакытта, 1914 тән, юридик ф-т сәркәтибе. 1908 дә һәм 1913 тә чит илдә стажировка уза. 1905 тән кадетлар партиясенең Казан губерна бүлекчәсе әгъзасы, 1906 дан партия бүлекчәсенең шәһәр ком-ты әгъзасы, 1917 нең 27 февралендә Казан ком-ты рәисе итеп сайлана. 1917 нең яз һәм җәй айларында Казан губернасында партияне ныгыту буенча күп эш башкара. Кадетлар партиясенең 3 губерна съездында рәислек итә. 1917 нең августында Казан шәһәр думасы гласные итеп сайлана. Казан җәмәгать иминлеге ком-тының хокук комиссиясе әгъзасы. Учредительләр җыенына сайлауларда катнаша, әмма тиешле санда тавыш җыя алмый. Совет хакимиятенә каршы чыгышлары б-н мәгълүм. 1917 нең 30 ноябрендә кулга алына, әмма дәлилләр булмау сәбәпле иреккә чыгарыла. Алга таба иҗтимагый-сәяси эшчәнлектән ерагая. 1918 нең көзендә, Кызыл Армия Казанны алганнан соң, шәһәрдән китә, 1919 ның 1 нче гыйнварында Казан ун-тыннан куыла. Томск ун-тында укыта. Хезмәтләре гражданнар, сәүдә һәм авторлык хокукына карый. Казан юридик җәмгыяте әгъзасы.

Х е з м.: О возмещённом отчуждении и приобретении вещей в собственность. М., 1914; Влияние момента безвозмездности в гражданском праве. К., 1916; Действующее крестьянское право. К., 1917.

*Әд.:* Е м е л ь я н о в а И.А. Юридический факультет Казанского государственного университета. 1805–1917: Очерки. К., 1998; Профессора Томского университета: Биогр. словарь. Томск, 1998. Т. 2; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.


*С.И.Ионенко.*

**СИМОЛИ́Н** Борис Николаевич (23.9.1900, Мәскәү — 19.8.1965, шунда ук), барон, актёр, режиссёр, педагог. 1914–18 елларда Казандагы Икенче ир балалар гимназиясендә укый. 1918 дә Кызыл Армиягә мобилизацияләнә, аның частьлары б-н Иркутскига кадәр барып җитә. 1920–22 дә Иркутск драма театры каршындагы студиядә укый, бер үк вакытта әлеге театрның актёры була, 1922 дән Н.П.Охлопков җитәкчелегендәге «Яшь театр» («Молодой театр») актёры. 1923 тә Казанга килә; Казан Зур драма театры студиясендә укучылар төркеме һәм һәвәскәрләр б-н берлектә «КЭМСТ театр тамашалары остаханәсе»н оештыра, әлеге театрда гадәти булмаган формасы, ачык публицистик юнәлеше, сәнгатьчә чараларның новаторларча кулланылышы б-н театр җәмәгатьчелеге арасында бәхәс тудырган шактый гына спектакльләр куя. С. тарафыннан куелган «Степан Разин» (В.В.Каменский), «Мистерия-буфф» (В.В.Маяковский), «Гамлет» (У.Шекспир), «Дөньяны тетрәткән ун көн» («Десять дней, которые потрясли мир», Дж. Рид әсәре буенча) спектакльләре Казанның 1920 еллар театр тормышында вакыйга була, алар театр сәнгатенең алга таба үсешенә зур йогынты ясый. 1924–28 дә Татар театр техникумында укыта, уку бүлеге б-н җитәкчелек итә, методик ярдәмлекләр төзи. Аның шәкертләре арасында Х.*Сәлимҗанов*, Р.*Ишморат*, Ф.Саллави, Г.*Нигъмәтуллина*, Г.*Булатова* була. Бер үк вакытта, 1926–28 дә, Татпрофсоветның Күчмә театры б-н җитәкчелек итә. 1928 дән Мәскәүдә, театр югары уку йортларында укыта.

*Әд.:* Б л а г о в Ю.А. КЭМСТ и театральная жизнь Казани 1920-х гг. К., 2005.

*Ю.А.Благов.*

**СИ́МОНОВ** Иван Михайлович (20.6.1794, Әстерхан ш. — 10.1.1855, Казан), астроном, Петербург ФА мөхбир әгъзасы (1829), Казан ун-тының атказ. профессоры (1841), *Казан астрономия фәнни мәктәбенә* нигез салучыларның берсе. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1812), шунда ук эшли, проф. (1816 елдан), шәһәр астрономия обсерваториясен җитәкли (1816–50), физика-матем. ф-ты деканы (1822–30), проректор (1845), ректор (1846–55). Бер үк вакытта Казан ун-ты каршындагы пед. ин-тының директоры (1831–33).


РУКОВОДСТВО
КЪ
УМОЗРИТЕЛЬНОЙ АСТРОНОМІИ
Ивана Симонова,
ЧАСТЬ ПЕРВАЯ
УРАНОМЕТРІЯ
КАЗАНЬ,
1832.

И.М.С и м о н о в. Күзәтүләр астрономиясенә кулланма. Казан, 1832. 1 нче кисәк. Уранометрия. Титул бите.



И.М. Симонов.

Казанда, Казан ун-ты каршында шәһәр астрономия (1833) һәм магнит (1842) обсерваторияләрен оештыручыларның берсе; С. тырышлыгы б-н Казан астрономия обсерваториясендә анналлар (хезмәтләр) нәшер итү башлана (1842). Галим-астроном буларак, С. Ф.Ф.Беллинсгаузен һәм М.П.Лазарев җитәкчелегендә «Мирный» һәм «Восток» шлюпкаларында дөнья тирәли хәрби-диңгез экспедициясе (1819–21) составына кертелә, бу экспедиция 1820 елның 28 гыйнварында Антарктида материгын ача; ш.у. метеорологик, гляциологик, гидрогеологик, магнитик һ.б. фәнни күзәтүләр һәм тикшеренүләр алып бара. Координаталарның астр. билгеләмәләре нигезендә С. Петр I утравын, Александр I Җирен һәм Төньяк Шетланд утраулары төркемендә Россия экспедициясе ачкан берничә утрауны карталарга төшерә. Яктырткычларның үлчәнгән биекләкләре буенча җирле вакытны билгеләүнең үзенчәлекле алымын эшли. Россиядә беренчеләрдән булып Җир магнетизмын өйрәнүгә керешә. Казан, Сембер, Оренбург губерналарында күп кенә торак пунктларның геогр. координаталарын билгели. Казан шәһәр обсерваториясендә йолдыз тупланышларына (беренче чиратта, Иләк йолдыз) һәм 1846 да ачылган Нептун планетасына күпсанлы күзәтүләр үткәрә. Хезмәтләре күзәтүләргә нигезләнгән астрономиягә, геодезиягә, Җир магнетизмына карый. Астрономик инструментларны камилләштерү б-н шөгыльләнә. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә Изге Владимир орденнары б-н бүләкләнә. Тын океанның көньяк өлешендәге утрауга һәм Петр I утравының төньяк-көнчыгыш борынына С. исеме бирелә, Антарктида картасында аның исеме 2 борынга һәм калкулыкка төшерелә. Казан ун-ты бинасына мемориаль такта куелган.

Х е з м.: Астрономические и физические наблюдения профессора Симонова, деланные во время путешествия его около света. СПб., 1828; Опыт математической теории земного магнетизма // Уч. зап. Казан. ун-та. 1835. Кн. 3; Записки и воспоминания о путешествии по Англии, Франции, Бельгии и Германии в 1842 году. К., 1844.

*Әд.:* Рассказы о Казанских учёных. К., 1983; С а х и б у л л и н Н.А. Дух просится вперёд: Движение жизни И.М.Симонова // Казань. 1999. № 7/8.

*Р.Г.Усманов.*

**СИ́МОНОВ** Михаил Васильевич (1.8.1913, хәзер Украина Респ-касы, Донецк өлкәсенең Амвросиевка р-ны Кутейниково пос. (Войково штп) — 24.4.2004, Казан), Сов. Союзы Герое (31.12.1942), гв. полковнигы. Көньяк тимер юллары уку-укыту комбинатын (Харьков ш., 1932), Гражданнар һава флотының Балашов очучылар мәктәбен (1935), офицерлар составының белемен күтәрү курсларын (1947) тәмамлый. 1929–30 елларда Горловка шәһәрендә (Украина ССР) заводта эшли. 1935–40 та Гражданнар һава флоты-



М.В.Симонов.

ның Ерак Көнчыгыш идарәсендә (Хабаровск ш.) «Владивосток-Могоча» трассасы пилоты. 1937 дә экипаж составында Хабаровск–Николаевск–Амур–Охотск–Нагаев култыгы–Петропавловск-Камчатский маршруты буенча очыш ясый. 1940 тан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 3 нче ерак араларга очу авиация дивизиясенең 2 нче гв. авиация полкында звено командиры. Мәскәү янындагы (1941–42), Ленинград (1941–44), Сталинград (1942–43) өчен, Курск дугасында (1943) барган сугышларда катнаша. Сугыш елларында гв. майоры С. 278 сугышчан очыш ясый, дошманның 7 истребителен бәреп төшерә. Сугыштан соң Ерак Төньякта хәрби очучы булып хезмәт итә. 1949 да, «Төньяк полюс-2» арктик экспедициясе әгъзаларын илтүче буларак, дөньяда беренче булып Төньяк полюска авыр бомбардировщик төшереп утырта. 1950–61 дә Казан авиация з-дында очучы-сынаучы, очучылар отряды командиры була. 1961 дә отставкага чыга. Өч Ленин ордены, ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Казандагы бер урам С. исемен йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СИ́МОНОВ** Михаил Петрович (19.10.1929, Ростов-Дон ш. — 4.3.2011, Мәскәү), авиаконструктор, техник фән. д-ры (1998), проф. (1983), Россия Герое (1999), Мәскәү авиация технол. ун-тының мактаулы техник фән. д-ры (1997), Казан техник ун-тының мактаулы проф. (1997). 1954 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук самолёт конструкцияләре һәм аларны проектлау кафедрасында эшли. Студентларның конструкторлык түгәрәге җитәкчесе (1954–56), илдә беренче студентлар КБларның берсен (1959 дан — спорт авиациясенең союзкүләм тәҗрибә КБ) оештыра (1956) һәм аны җитәкли. С. җитәкчелегендә спорт планеры КАИ-6, илдә беренче тоташ металл планерлар — КАИ-11, КАИ-12, КАИ-14, КАИ-19 эшләнә һәм серияләп җитештерүгә кертелә (ике урынлы КАИ-12 «Приморец» планеры зур серия б-н чыгарыла: 800 тирәсе эшләнмә; КАИ-19 планерында берничә дөнья рекорды куела). 1969 дан Авиация сәнәгате министрлыгы пр-тиеләрендә эшли: Долгопрудный (Мәскәү өлкәсе) автоматика КБнда, Таганрог машина төзү з-дында баш конструктор урынбасары. 1970 тән П.О.Сухой исем. тәҗрибә КБнда (Мәскәү): баш конструктор урынбасары, баш конструктор (1977 дән), ген. конструкторның 1нче урынбасары, ген. конструктор (1983 тән), ген. директор (1993–99). 1979–83 тә СССР авиация сәнәгате министры урынбасары. С. җитәкчелегендә югары манёврлы уникаль сугышчан Су-27, Су-30, Су-32 ФН, Су-33, Су-35, Су-37 самолётлары; пилотажлы Су-26, Су-29, Су-31 спорт самолётлары (дөньяның күп илләренә чыгарыла) эшләнә; гражданлык самолётлары (йөк-пасс, а.х., пасс.) эшләнә башлый. 1989–91 дә СССР ЮС депутаты. Ленин бүләге (1976), РФ Дәүләт бүләкләре (1998, 1999) лауреаты. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. С. исеме Вашингтондагы Милли авиация һәм космонавтика музееның Мактау тактасына кертелгән.



М.П.Симонов.

*Әд.:* Л о к ш и н М.А., Ш а р и ф у л л и н а Л.К., Ш а т а е в В.Г. Манёвренные самолёты ОКБ Сухого // Изв. вузов. Авиац. техника. 1999. № 3; Ш а т а е в В.Г. Человек-легенда // Казань. 1999. № 3/4.

**СИ́МОНОВА** Лариса Анатольевна (10.8.1963, БАССРның Туймазы ш.), җитештерү б-н идарә итү системалары өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2005). 1986 елда Уфа авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Талды-Курган шәһәрендәге (Казахстан ССР, 1986–90) СПТУда укыта. 1990 нан Казан ун-тының Чаллы ин-ты информацион технологияләрне автоматлаштыру кафедрасында. Хезмәтләре җитештерү б-н идарә итүнең бердәм информацион моделен кабул ителгән карарларны үтәтү системаларын кулланып төзүгә, аның методологик һәм теоретик нигезләрен булдыруга, тикшерү процедураларын гамәлгә ашыруга, технологик әзерлек этабында барлык кирәкле үзгәрешләрне чагылдыра баруга карый.

Х е з м.: Методология построения интегрированного информационного обеспечения гибких производственных систем механической обработки на машиностроительных предприятиях. СПб., 2004; Управление процессом обработки партии деталей. Наб. Челны, 2004; Интегрированное информационное обеспечение процесса управления технологическими маршрутами в рамках ERP-системы. М., 2005 (автордаш).

**СИМУНО́В** Леонид Васильевич (9.12.1929, Буа кантоны Күшке а.), агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Тәтеш а.х. техникумын (1965), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлый (Мәскәү, 1971). 1941–90 елларда Буа р-нында эшли, Мичурин исем. к-зда кырчылык бригадасы бригадиры (1946 дан), баш бухгалтер (1953 тән), к-з рәисе (1958 дән), «Гигант» к-зында рәис урынбасары (1960 тан), партком секретаре (1964 тән). «Рассвет» к-зы рәисе (1974 тән). С. җитәкче булганда «Рассвет» к-зында 1 мең баш мөгезле эре терлек өчен бина, 3 мең баш дуңгыз өчен ферма, 360 урынга урта мәктәп, балалар бакчасы; утар тибындагы 56 йорт, а.х. техникасы, ашлама һәм печән өчен 16 ангар; суның күләме 5 млн. *м*³ булган плотина, 1400 *га* сугару системалары, 20 *км* асфальт юл, сууткәргеч һ.б. җитештерү, социаль-мәдәният һәм көнкүреш биналары төзелә; Корбаш, Мөкерле, Отрада, Протопопово авылларына газ кертелә. Шикәр чөгендерен җитештерү 26,6% ка, ит — 38,8% ка арта, бөртеклеләрнең уңышы 1 *га* дан 33,5 *ц* га, шикәр чөгендере — 483 *ц* га җитә; еллык савым һәр сыердан уртача 3700 *кг* тәшкил итә. 1980–85 елларда ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, ике «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**СИМФО́НИК МУ́ЗЫКА**, симф. оркестр өчен иҗат ителә. С.м. жанрына симфония, симф. поэма, картина, увертюра, фантазия, сюита, инструменталь концерт керә. С.м. традицияләре 18 йөз Көнбатыш Европа музыкасында барлыкка килә. Рус музыкасында алар 19 йөздә М.Глинка, П.Чайковский, А.Бородин иҗатларында үсеш ала. Татар С.м.сының барлыкка килүе 20 йөзнең 1 нче яртысына, милли проф. композиторлык мәктәбенең формалашуы һәм үсеше чорына туры килә. Татар С.м.сына рус С.м.сы принциплары нигез була (иң мөһиме — фольклор традицияләренең һәм европача акад. язу кануннарының үзара бәйләнеше). Беренче тәҗрибәләр, башлыча, В.И.*Виноградовның* татар һәм башкорт халык көйләренә нигезләнгән «Татар сюитасы» (1921) һәм «Шихан» (1924) симф. картинасы була. С.м. иҗатының алшартлары С.Җ.*Сәйдәшевнең* муз. драмаларында (инструменталь фрагментлар: увертюра, марш, бию, сюита һ.б.), аның беренче опера һәм балет әсәрләрендә, халык көйләренең симф. эшкәртмәләрендә, оркестр миниатюраларында туа. 1930–40 елларда Н.Г.*Җиһанов* (1937), Ф.З.*Яруллин* (1938), М.Ә.*Мозаффаровның* (1944) беренче симфонияләре, А.С.*Ключарёвның* «Галиябану» сюитасы (1933), «Татар сюитасы» (1945), ш.у. А.С.*Леманның* 2 нче Фортепиано концерты (1944) — беренче татар инструменталь концерты языла.

Сугыштан соңгы чорда С.м.ның жанр диапазоны сизелерлек киңәя. А.С.Ключарёвның яңа симфониясе («Идел симфониясе», 1955), А.Г.*Вәлиуллин*, А.С.Леман, Н.Г.Җиһанов, А.С.Ключарёв сюиталары б-н беррәттән беренче симфоник поэмалар — Н.Г.Җиһановның «Кырлай» (1946), М.Ә.Мозаффаровның «Г.Тукай истәлегенә» (1952) һәм «М.Вахитов истәлегенә» (1956), А.Г.Вәлиуллинның «Спас күтәрелеше» (1956), Н.Г.Җиһановның «Намус» (1952) увертюрасы, Р.Г.*Гобәйдуллин*, А.С.Леман, Б.Г.*Мөлеков* һ.б.ның әсәрләре, ш.у. А.С.Леманның «Татар рапсодиясе» (1955) иҗат ителә. 1950 елларда концерт жанрының классик үрнәкләре: Р.М.*Яхинның* Фортепиано концерты (1951), А.С.Леман (1951) һәм М.Ә.Мозаффаровның (1959) беренче скрипка концертлары барлыкка килә. Татарстан композиторларының әсәрләре бөтенсоюз танылуы ала, Н.Г.Җиһановның Татар темаларына сюита (1950) һәм А.С.Леманның 1 нче Скрипка концерты (1951) СССРның Дәүләт премияләренә лаек булалар.

1960 елларда С.м. үсешендә яңа этап — татар проф. музыкасының иҗади өлгергәнлек чоры башлана. Н.Г.Җиһановның 2 нче «Сабантуй» симфониясе (1968; СССР Дәүләт премиясе, 1972), А.З.*Монасыйповның* 1 нче, 2 нче симфонияләре (1964, 1968), Ф.Ә.*Әхмәтовның* «Ф.Яруллин истәлегенә» поэмасы

(1969; РСФСР Дәүләт премиясе, 1975) иҗат ителә. Элекеге юнәлешләр (лирик-жанр, эпик симфонизм) б-н беррәттән лирик-психол., драматик симфонизм (А.З.Монасыйпов, Ф.Ә.Әхмәтов, Н.Г.Җиһанов, Р.Ә.*Еникиев* әсәрләре) туа. Инстр. концертның шәрехләмәсе стиль ягыннан күптөрле һәм үзенчәлекле була бара: Р.Ә.Еникиев (1961), Р.Н.*Беляловның* (1966) фортепиано концертлары, М.З.*Яруллинның* Скрипка концерты (1962), А.С.Леманның Оркестр өчен концерты (1968), Р.Г.Гобәйдуллин, И.Д.*Якупов* әсәрләре; Н.Г.Җиһанов («Симфоник новеллалар», 1964; «Симфоник җырлар», 1965), М.З.Яруллин («Балалар сюитасы», 1969) сюиталары; муз.-сәхнә әсәрләре җирлегендә сюиталар иҗат ителә. 1967 дә ТР Дәүләт симф. оркестры оешу (баш дирижёры — Н.Г.*Рахлин*) һәм респ-када башкару осталыгы камилләшү татар С.м.сы үсешенә көчле стимул була.

Шуннан соңгы елларда С.м. бик тиз һәм төрле яклап үсеш ала. Н.Г.Җиһанов иҗатында симф. төп жанр булып китә (3–17 нче симфонияләр языла). А.З.Монасыйповның 3 нче, 4 нче симфонияләре (1974, 1980), «Идел-йорт» поэмасы (1994), «Бәйрәм увертюрасы» (1977), «Сәйдәшевкә музыкаль бүләк» (1990); Ф.Ә.Әхмәтовның «Казан» симфониясе (1976), «Татарстан» увертюрасы (1979), фортепиано (1983) һәм скрипка (1991) концертлары; Р.Н.Беляловның оркестр б-н фортепиано өчен (1970), оркестр б-н скрипка өчен (1984) концерт-каприччиолары; Оркестр б-н скрипка өчен концерт-симфониясе (1974); Р.Ә.Еникиевнең «Крыловка ияреп дүрт мәсәл» (1977), «Рапсодия», Оркестр б-н виолончель өчен диптих (икесе дә — 1986), Оркестр б-н скрипка өчен триптих (1997) кебек шактый әсәрләр туа. А.Б.*Луппов* та үзеннән зур өлеш кертә: 12 симфония, шулар арасында аеруча игътибарга лаеклылары: 2 нче «Дала курае» (1987), 3 нче «Сөембикә манарасы риваяте» (1989), 7 нче «Кара урман» (1995), 8 нче «Н.Җиһанов истәлегенә» (1997) симфонияләре; соло башкаручы төрле уен кораллары өчен 12 концерт, увертюралар, сюиталар. Бу әсәрләр хәзерге заман татар музыкасының казанышлары булып санала, киң танылу алып, Композиторлар берлеге съездлары һәм пленумнарында, Мәскәүдә, С.-Петербургта һ.б. концертларда башкарыла. Хәзерге заман музыкасының яңача үсеш юнәлешләре С.Ә.*Гобәйдуллина* әсәрләрендә чагыла.

1970–2000 елларда С.м. б-н яшь буын композиторлар ныклап кызыксына башлый: Р.З.*Ахиярова* — «Кол Гали» (1988) симфониясе, Г.Тукай истәлегенә «Моңлы сазым» (1986) поэмасы; И.И.Байтирәк — 2 симфония (1993, 2005), «Татарстан» (1995) увертюрасы, С.Сәйдәшевкә музыкаль бүләк — «Гөлнара» (2001) поэмасы; Ш.Х.*Тимербулатов* — 3 симфония (1978, 1994, 2000), концертлар, симф. күренешләр; М.И.*Шәмсетдинова* — «Дастан» (1999), «Ибне Фадлан» (2001), «Чыңгызхан» (2004) симфонияләре; Ш.К.*Шәрифуллин* — 2 симфония (1973, 1980), «Җыен» оркестры өчен концерт (1982). 21 йөз татар С.м.на Р.Ф.Кәлимуллин зур өлеш кертә: 2 симфония (2000, 2009), «Минем Татарстаным» увертюрасы (2007), Оркестр өчен концерт (2008), 10 концерт: оркестр б-н соло башкаручы уен кораллары өчен, «Гавай утраулары» (2004), «Пальмира күренеше» (2006), «Риваять», «Илем даны» (икесе дә — 2007) һ.б.

Соңгы чорлар С.м.нда композиторлар драматик концепцияләр гәүдәләнешенә омтылалар. Жанрлар композициясе һәм драматургиясе иркенрәк, үзенчәлеклерәк интерпретацияләнә башлый. Жанрларның бер-берсенә йогынтысы, үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсендә симф.-поэма («Муса Җәлил», А.З.Монасыйпов, 1972; «Болгарлар», Р.Ф.Кәлимуллин, 1986), увертюра-фантазия («С.Сәйдәшев темаларына увертюра-фантазия», А.С.*Миргородский*, 1983), концерт-поэма («Казан турында риваять», Р.Ф.Кәлимуллин, 2004), концерт-симф. (Р.Н.Белялов, 1974; С.В.Зорюкова, 1997; В.В.Харисов, 1998 әсәрләре), концерт-рапсодия (Ш.Х.Тимербулатов, 2000; В.В.Харисов, 2006 һ.б.) кебек әсәрләр туа. Соло башкаручы уен кораллары даирәсе шактый киңәя, алар өчен махсус концертлар иҗат ителә. Күп санлы фортепиано һәм скрипка концертлары б-н беррәттән флейта, кларнет, труба өчен (Р.Ф.Кәлимуллин әсәрләре), виолончель, фагот, саксофон, валторна, гитара, думбра өчен (И.И.Байтирәк, Р.Ф.Зарипов, Р.В.Ильясов, Р.Ф.Кәлимуллин, Л.Ә.*Хәйретдинова*, В.В.Харисов) әсәрләр барлыкка килә. С.м.ның татар музыкасы өчен яңа жанр төрлелеге: каприччио, вариацияләр һ.б. жанр кысаларына кермәгән үзенчәлекле программ исемле әсәрләр үзләштерелә.

Әлеге этапта композиторлар тарафыннан мәңгелек гомумкешелек кыйммәтләре дөньясы, явызлык һәм игелек, әхлак һәм әхлаксызлык каршылыгы, татар халкы тарихының һәм хәзерге чорның актуаль проблемалары ачыла.

Татар С.м.ның аерым үзенчәлеге — әсәрләрнең фольклор музыкасы традицияләре б-н тыгыз элемтәсенә бәйле ачык милли төсмерләре булуында. Бик күп әсәрләр темасының нигезендә — чын халык көйләре; алар шунда үсеш ала, үзгәрә, үзенең бай, тирән мәгънәле потенциалын ача. Әсәрләрнең күпчелеге халык көйләре традицияләре б-н турыдан-туры бәйләнештә түгел, аларда төрле фольклор жанрларының (озын көйләр, такмаклар, авыл көйләре һ.б.) гадәти үзенчәлекләре, мөнәҗәтләр, китапча көйләү, гыйбадәт музыкасы, ш.у. гомумән халыкның музыкаль фикерләү принциплары гамәлгә ашырыла. 1930–50 елларда Татарстан композиторлары жанрлар интерпретациясендә шактый дәрәҗәдә рус классик музыкасы традицияләренә йөз тоткан булсалар, 1960–2000 елларда алар өчен 20 йөз илебез һәм чит ил музыкасының яңалык кертү тәҗрибәсе актуальрәк була бара. 20 йөз музыка сәнгате корифейлары И.Стравинский, С.Прокофьев, Д.Шостакович, Б.Барток, А.Берг һ.б. традицияләренең иҗади үзгәреше (Ф.Ә.Әхмәтов, Р.Н.Белялов, Р.Ә.Еникиев, Р.Ф.Кәлимуллин, А.Б.Луппов, А.З.Монасыйпов, Ш.К.Шәрифуллин әсәрләрендә) милли образлылык чикләрен киңәйтүгә, татар музыкасының яңа тәэсирлелек потенциалын ачуга булышлык итә. С.м. жанрларының классик кануннарына таянып, аларны аңнары аша үткәреп, Татарстан композиторлары хәзерге заман музыка мирасына зур өлеш кертәләр.

*Әд.:* Шумская Н. Татарская симфоническая музыка // Музыкальная культура Советской Татарии. М., 1959; Алмазова Т. Симфоническая поэма в татарской музыке // Музыкальная культура народов Поволжья: Сб. науч. работ. М., 1978; шул ук. Татарский инструментальный концерт: Пути становления и развития. К., 2000.

*Т.А.Алмазова.*

**СИНАГО́ГА**, Казанда архит-ра истәлеге. Казанда яһүдләр җәмгыяте 1847 елга кадәр эшли. Вакытлыча файдалануга алынган бүлмәләрдә урнаша. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Кече Проломный урамындагы йортта урнаша (хәзерге Профсоюз урамы). Дәүләт банкы төзелеше башлангач, ул сүтелә, җәмгыятькә Кече Проломный урамының икенче ягында үзләренең С. бинасын төзергә рөхсәт ителә. Бина 1914–15 тә арх. Н.М.Андреев проекты буенча җәмгыять акчасына төзелә. Россия кануннары нигезендә, яһүдләрнең «утраклык чигеннән» арырак губерналарда урнашкан яһүди гыйбадәтханәләрнең тышкы ягында архитектур һәм сынлы дини символлар (алты почмаклы йолдыз,



Казандагы синагога. Хәзерге күренеше.

менора (җиде кәүсәле шәмдәл һ.б.) куелырга тиеш булмый. С. — модерн стилендә төзелгән өч катлы кирпеч бина. Төп фасадының үзәк өлеше аттиклы һәм дагасыман ике уемлы. Аларның берсе — ишегалдына узу, икенчесе төп ишектән керү өчен хезмәт иткән. Аттиктагы икешәр катлы кечкенә тәрәзәләр изге язулы тактага охшатып ясалган, аларны камалап алган декоратив элементлар Тора төргәкләрен хәтерләтә, баскыч култыксасындагы рәсемдә алты почмаклы йолдыз сурәте бар. Ике рәт тәрәзәле гыйбадәт залының кеше күзеннән читтә урнашкан ишегалды фасадында шәрекъ сыйфатларын абайларга була. Залның күләме урам яктагы корпуска перпендикуляр тора. 1929 да С. ябыла, соңрак бина — яһүд мәдәнияте йорты, аннары пионерлар, мәгариф хезмәткәрләре йорты була. 1940 та Укытучылар йортын урнаштыру өчен арх. Р.М.Мортазин проекты б-н төп фасадны неоклассицизм стилендә бизәп, планында

һәм интерьерларда үзгәрешләр кертеп, капиталь реконструкция үткәрелә. Гыйбадәтханәнең төньяк дивары буйлап зал б-н тоташтыручы ике баскычлы агач сәхнә урнаштырылган. 1996 да бина яһүдләр җәмгыятенә тапшырыла, 1990 еллар ахырында капиталь ремонт үткәрелә. Төп гыйбадәт залының интерьеры үзгәртелә. Элеккеге сәхнәне калган өлештән аркалы, биш кырлы, киң уемлы, баганалар шикелле үк куе зәңгәр керәч плитә б-н бизәлгән дивар аерып тора. Диварның өске өлешендә җиз хәрефләр б-н язу язылган. Зәңгәр дивар яссылыгында сул якта — Иерусалим храмы хәрабәләре, уң якта борынгы яһүд шәһәре шәүләсе чалымлана. Сәхнәнең үзәк өлешендә изге Тора төргәкләре сакланган кечерәк нәфис киот куелган. Гыйбадәтханә залын сәхнә б-н бер маршлы баскыч тоташтыра. Залның үзәгендә изге сәхифәләр укыла торган подиумлы зур өстәл урнашкан. Зал ишеге өстендә хатын-кызлар өчен балкон куелган. Түшәмдәге алты почмаклы йолдызның үзәгенә эленгән, ян-яклардагы шәмдәлләр кебек үк җиздән эшләнгән люстра гыйбадәт залының төп бизәге булып тора.

*Әд.:* Нугманова Г.Г. Еврейский молитвенный дом в Казани в контексте российского архитектурно-строительного законодательства // Изв. Казан. гос. архитектурно-строительного ун-та. 2009. № 1 (11).

*Г.Г.Ногманова, Е.В.Липаков.*

**СИНА́ЕВ** Константин Иванович (28.2.1923, Лаеш кантоны Корноухово а. — 10.5.1981, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1970), проф. (1971). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), шунда ук эшли, югары молекуляр кушылмалар химиясе һәм технологиясе каф. мөдире (1976–81). Хезмәтләре куертылган системаларның януына карый. С. дары һәм каты ракета ягулыкларының яну механизмы турындагы төшенчәләрне формалаштыруга зур өлеш кертә. Чыганаклы-тибешле яну фаразын әйтә һәм аны исбатлый, шулай катлаулы дары яну процессы б-н идарә итү һәм дарылар януының гадәти режимнан тайпылышлары кебек алгарыш аңлату мөмкинлегенә туа. Аткан вакытта яну һ.б. процессларның бәйләнешен, технологик, химик һәм физик факторларның яну процессына тәэсирен өйрәнә. Кабызып җибәргәндә дары өслеге б-н тышкы җылылык агышы арасындагы җылылык бәйләнешен, процессның ялкынлануга һәм тотрыклы януга күчүгә кадәр үсешен тикшерә. 120 дән артык фәнни хезмәт авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**СИНГАЛЕ́ВИЧ** Сергей Платонович (25.9.1887, Волынь губ., Иске Константиновка өязе Красилово а. — 10.8.1954, Йошкар-Ола ш.), педагог, тарихчы. 1910 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1910–19 да Казан югары хатын-кызлар курсларында укыта. Бер үк вакытта, 1914–22 һәм 1932–37 дә, Казан ун-тында: 1918–22 дә гомуми тарих каф. профессоры, 1932 дән педагогика каф. мөдире һәм проректор. 1922–38 дә Казан пед. ин-тында: ректор (1922–29), проректор (1929–32). 1938 дә репрессияләнә, 1946 га кадәр тоткынлыкта була (1956 да үлгәннән соң аклана). 1946 дан Мари пед. ин-тының гомуми тарих кафедрасында проф. Тарих һәм җәмгыять белемен укыту методикасы буенча хезмәтләр авторы, аларда укучыларның дәрестә актив эшчәнлеген, күрсәтмә әсбапларны һәм экскурсияләрне киң куллану укыту процессының аерылгысыз өлеше итеп алына, тәрбия һәм укытуның новаторлык алымнары эшләнә. Идеологик тәрбия биргүгә, укучыларда коммунистик карашлар формалаштыруга зур игътибар бирә. С.ның гомуми тарих историографиясе буенча хезмәтләре вульгар социологизмга күчә баручы сугышчан марксистик карашлардан чыгып язылган.

Х е з м.: Методика истории: Принципы, теория и пути к практике. К., 1918; Лабораторное преподавание истории в школе первой ступени: Теоретические основы преподавания. К., 1921; Обществоведение в трудовой школе. К., 1925; Первый Интернационал в научной историографии. К., 1925; Великая французская революция: Очерки историографии. К., 1929.

*Әд.:* Адо В.И., Фишер И.Р. Сергей Платонович Сингалевич: творческий поиск. Судьба наследия // История и историография зарубежного мира в лицах. Самара, 1996. Вып. 1.

**СИНГАРМОНИ́ЗМ** (грек. sýn — бергә һәм harmonía — аваздашлык). Морфологик берәмлек буларак сүздә сузыкларның (вокаль), кайвакыт тартыкларның (консонант) аваз составы ягыннан охшашланып килүе. Нигездә, *агглютинатив телләргә* хас. Татар телендә вокаль С. гына күзәтелә. С.ның ике төре бар: рәт (аңкау) гармониясе һәм ирен гармониясе. Рәт гармониясе булганда, сүздә я алгы, я арткы рәт сузыклары гына кулланыла. Беренче иҗектә алгы рәт (нечкә) сузыгы икән, калган иҗекләрдә дә алгы рәт сузыгы була һәм киресенчә; мәс., к**е**ш**е**л**ә**рг**ә**, **а**тл**ы**л**а**рг**а**. Ирен гармониясе булганда, беренче иҗектәге иренләшкән [о], [ө] авазлары алардан соң килүче иренләшмәгән [ы] яки [е] авазларын иренләштерә, ягъни бу авазлар [о] яки [ө] булып яңгырый; мәс., борын [б**о**р**о**н], көлке [к**ө**лк**ө**]. Алардан аермалы буларак, иренләшкән [у], [ү] авазлары мондый ассимиляция күренешенә ия түгел. Язуда бары рәт гармониясе генә чагылыш таба.

*Әд.:* Татар грамматикасы. М.–К., 1998. Т. 1; Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. К., 2001; Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2002.

**СИНДРЯКО́В** Николай Кузьмич (1.1.1924, Чистай кантоны Иске Чаллы а. — 29.9.1943, Украина ССР, Киев өлкәсенең Мироновка р-ны Великий Букрин а.), Сов. Союзы Герое (17.11.1943), гв. лейтенанты. Саранск пехота уч-щесен тәмамлый (1943). Туган авылында колхозда эшли. 1942 елдан Кызыл Армия сафларында, 1943 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында (3 нче гв. танк армиясенең 7 нче гв. танк корпусы). Үзәк Воронеж фронты гаскәрләре составында Орёл операциясендә (1943), Сулъяк яр Украинаны азат итүдә (1943) катнаша. Киев өлкәсенең Мироновка р-нында Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: 1943 нең 22 сентябренә каршы төндә беренче булып елганы кичә; С. җитәкчелегендәге взвод дошман терр-ясенә үтеп кереп, батальонның елганы кичүен тәэмин итә. Сугышларның берсендә һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены һәм медаль б-н бүләкләнә. Малый Букрин авылында һәм Нурлат шәһәрендә бер урам С. исемен йөртә, туган авылында С.ка — бюст, Великий Букрин авылында мемориаль такта куелган.



Н.К. Синдряков.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СИНЕ́Р** посёлогы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 18 *км* көньяктарак, Кенә елгасының (Вятка бассейны) югары агымы буенда. 2010 елда 10 кеше (марилар, руслар) яши. 1638 елга кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында По речке Синер исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Изге Геннадий чиркәве, земство мәктәбе (1870 тә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 481,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әсән-Елга волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 44 ир-ат; 1859 да — 145, 1897 дә — 151, 1908 дә — 178, 1920 дә — 240, 1926 да — 239, 1938 дә — 190, 1949 да — 150, 1958 дә — 83, 1970 һәм 1979 да — 58 әр, 1989 да — 15, 2002 дә — 8 кеше.

**СИНЕСТЕЗИ́Я** (грек. synáisthēsis — сиземләү), билгеле бер ярсыткычка ярашлы һәм әлеге тәэсиргә тою органы өчен үзенчәлекле үзләштерү (кабул итү) күренеше. Еш кына ул башка модальлеккә хас өстәмә тойгы б-н кушылып китә. Лингвистикада «С.» термины — әлеге бәйләнешнең сүз б-н белдерелүе («кыкле-яшелле тавыш», «җылы төс»), поэтикада — хисләр күчешенә нигезләнгән троплар һәм фигуралар, музыка белемендә — аваз аша кабул ителгән муз. образлар (мәс., К.Дебюсси, Н.А.Римский-Корсаков, А.Н.Скрябин, О.Мессиан әсәрләре). Киңрәк мәгънәдә С. дип күрү һәм ишетү сәнгатьләренең (программалы музыка, төсле музыка, М.К.Чюрлёнис, В.В.Кандинский иҗатлары кебек С. жанрлары барлыгын истә тотып) үзара йогынтысын атыйлар. С. чынбарлыкның үзенчәлекләрен чагылдыра, сәнгати фикерләүнең аерылгысыз бер өлеше булып тора. С. әдәби һәм сәнгатьчә образ тудыруда, сәнгать төрләренең үзара тәэсир итешү һәм кушылу процессларында катнаша. Сәнгать киңлеге — вакытның күпкырлылыгы, төрле төрләргә бүленгән очракта да сәнгатьнең төп вазифалары саклану шуның б-н аңлатыла. Ише-

теп-күреп аралашуның техник чараларын (кино, телевидение, төсле музыка, мультимедиа) кулланучы яңа сәнгать төрләре барлыкка килгән чорда С. б-н кызыксыну аеруча көчәя.

С., аерым бер күренеш буларак, 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башында өйрәнелә башлый; Россиядә төп хезмәтләр Казан галимнәре тарафыннан языла. 1884 елда физиолог Н.О.Ковалевский «сиземләү» (С.нең калькалаштырылган тәрҗемәсе) терминын беренче тапкыр әйләнешкә кертә. Ковалевский һәм В.М.Бехтерев (1896) сиземләүне сәнгатькә бернинди катнашы булмаган реаль психик күренеш дип карыйлар.

Философ В.Н.*Ивановскийның* әле Казанда эшләгән елларында ук төп өйрәнү объекты ассоциацияләр була. Хезмәтләрендә ул С.не «икенчел ялган сиземләү» дип атый, шул тематиканы яктырткан Европа әдәбиятына күзәтүне, беренчеләрдән булып, рус телендә тәкъдим итә. Ивановский, Россиядә генә түгел, бөтен дөньяда беренчеләрдән булып, С.нең эчтәлегенә һәм роленә, мәдәният, тел һәм сәнгатьтәге аерым очрагына («төсле ишетү») бәя бирә.

Казан профессоры И.М.*Догель*, физиологиягә нигезләнгән «төс-тавыш» аналогиясен төзергә тырышып, музыка һәм төстән алган тәэсирләр арасында охшашлыклар барлыгын әйтеп китә. Ул пластик С., ягъни халык җырларына хас көй бизәлешләренең шул халык яшәгән җирлек рельефы б-н охшашлыгы турында да уйлана. Догель, «төсле ишетү» билгеләмәсен кулланып һәм аның ассоциатив табигате турында әйтеп, музыканың һәм төсләрнең нерв системасына тәэсирен өйрәнә.

Казан физиологы А.Ф.*Самойлов* музыканы физиол. методлар кулланып өйрәнә (1919). Ул фикер йөртүгә нигезләнгән ишетү һәм күрү күренешләрен чагыштыра һәм шуның б-н синестезик эчтәлекле чагыштырулар оештыра торган уртак буыннар барлыгын дәлилли.

С.не өйрәнү дәверендә эстетика һәм психология С. табигатенең агностик, механистик һәм биологизатор аңлатмалары йогынтысын тоялар. Алар бүгенге көндә дә һәм Россия, һәм Көнбатыш фәнендә чагылыш таба. Беренче чиратта бу юк-бар буларак кабул ителгән С.не сенсор дәрәҗәдә чын сиземләү дип аңлау.

С.нең чын эчтәлеген һәм аның сәнгатьтәге урынын билгеләүдә «Farbe-Tan-Forschungen» («Төсле тавышны өйрәнү», Гамбург, 1927, 1929, 1931, 1936) конгрессының роле зур.

1960 еллар ахырыннан Казан «*Прометей*» фәнни-тикшеренү ин-ты С.не өйрәнү үзәгенә әверелә. Ул оештырган бөтенсоюз «Яктылык һәм музыка» (1969, 1975, 1979, 1987) конференцияләре, Б.М.*Галиев*, И.Л.Ванечкина һ.б.ның тикшеренүләре С.не өйрәнүгә әһәмиятле өлеш кертә.

*Әд.:* Галеев Б.М. Человек, искусство, техника: Проблема синестезии в искусстве.. К., 1987; Синестезия: Содружество чувств и синтез искусств: Сб. статей. К., 2008.

*Б.М.Галиев.*

**СИНИ́ЦЫН** Олег Владимирович (11.3.1957, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (2000), проф. (2003). 1979 елда Казан пед. ин-тын (хәзер Казан (Идел буе) федераль ун-ты) тәмамлый, 1980 нән шунда ук эшли: татар филологиясе һәм тарихы (1991–95), тарих ф-ты (1995–96, 2001–04, 2009–11) деканы, Россия тарихы каф. мөдире (2004–08). Тарих ин-тының историография бүлеге мөдире (2011–13), Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү ин-тының историография каф. мөдире (2013–14), Россия һәм якын чит илләр тарихы каф. профессоры (2014 тән). Хезмәтләре Россия историографиясенә, тарих фәне методологиясенә, Россия һәм Татарстанда мәгариф тарихына карый. С. историография тикшеренүләренең 19 йөз ахыры — 20 йөз башы Россия тарихы теориясе һәм методологиясендә неокантлык агымы дип исемләнгән аерым тармагын эшли.

Хезм.: Кризис русской буржуазной исторической науки в конце XIX — начале XX вв.: Неокантианское течение. К., 1990; Неокантианская методология истории и развитие исторической мысли в России в конце XIX — начале XX вв. К., 1998; Судебная власть и судебная система России. К., 2004 (автордаш).

**СИННИ́НГИЯ**, к. *Глоксиния*.

**СИНО́Д ФӘРМАНЫ́**, (1773 ел, 17 июнь, «О терпимости всех вероисповеданий и о запрещении архиереям вступать в разные дела, касающиеся до иноверных исповеданий и до построения по их закону молитвенных домов, предоставляя все сие светским начальствам»), барлык диннәргә карата да сабыр, түземле караш булдыру, урындагы христиан дине башлыкларына башка диндәгеләрнең, ш.и. мөселманнарның эшенә тыкшынмау, аларның гыйбадәт йортларына кагылмау турындагы фәрман. Фәрманның гамәлгә кертелүе Казан архиепископы Вениаминның, Казанда һәм татарлар б-н яңа гына чукындырылган кешеләр бергә тупланып яшәгән урыннарда мәчетләр салына башлавының моңа кадәр кабул ителгән законнарга каршы килүеннән чыгып, шикаять белдерүе б-н бәйле. Әлеге мәсьәләне тикшерү б-н Сенат шөгыльләнә, бу эшкә Екатерина II дә турыдан-туры катнаша. Аның фикере б-н килешеп, Синод архиерейларны мөселманнарның һәм «башка диндәгеләрнең» эшләренә, ш.и. «аларның гыйбадәт йортларындагы тәртипләргә» кагылудан һәм катышудан тыя. Киләчәктә Россиядә христиан динендә булмаган халыкларның дини мәсьәләләре дәүләт оешмалары тарафыннан гына хәл ителергә тиеш, дип белдерелә. С.ф. (1773 ел, 17 июнь) Екатерина II тарафыннан игълан ителгән барлык диннәргә карата сабыр, түзем булу сәясәте символына әверелә һәм Россиянең законнар чыгару тәҗрибәсендә киң кулланыла.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 19. № 13996.

*Әд.:* Ногманов А.И. Татары Среднего Поволжья и Приуралья в российском законодательстве второй половины XVI–XVIII вв. К., 2002.

*А.И.Ногманов.*

**СИНО́НИМНАР** (грек. synṓnymos — бер исемле), яңгырашлары б-н бер-берсеннән аерыла торган, ә мәгънәләре ягыннан охшаш яисә якын мәгънәле, мәгънәдәш сүзләр, ш.у. мәгънәләре ягыннан бер-берсенә туры килүче синтаксик һәм грамматик төзелмәләр. Телдә С. алыштыру, аныклау һәм бәяләү функцияләрен башкаралар, алар текст эчендәге теге яки бу сүзләрнең кабатлануыннан качу, предмет һәм күренешне тулы, төрле яклап тасвирлау мөмкинлеге тудыралар. Татар телендә С.ның 4 төрен аерып карыйлар. Идеографик (семантик) С. мәгънә төсмерләре б-н аерылып торалар, теге яки бу күренешне төрле яклап ачыклыйлар: аяз — болытсыз — кояшлы — якты һ.б. Стилистик С.ның мәгънәләре бертөрле булса да, кулланылыш дәрәҗәләре төрле: сандугач — былбыл. Сандугач — гомумкулланылыштагы сүз, былбыл — китап стиле, шигъри тел өчен отышлы. Семантик-стилистик С. мәгънә төсмерләре б-н дә, стилистик төсмерләре б-н дә аерыла: укытучы — остаз һ.б. Абс. С. мәгънәләре ягыннан да, стилистик яктан та бер-берсеннән аерылмый: кебек — шикелле. Андый С.ның берсе (кайвакыт икесе дә), кагыйдә буларак, алынма сүз була: дивар — стена, китапханә — библиотека, тел белеме — лингвистика. Телнең үз лексик системасына хас булган тел С.ыннан тыш, билгеле бер контекстта, вакытлыча гына синоним булып килүче контекстуаль С.ны да аерып карыйлар; мәс., Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасында урман сарыгы сүзтезмәсе шүрәленең синонимы булып тора. Татар синонимиясенең нигезләре Ш.С.Ханбикова хезмәтләрендә өйрәнелгән.

*Әд.:* Ханбикова Ш.С. Татар телендә синонимнар. К., 1961; шул ук. Татар телендә синонимия һәм сүзлекләр. К., 1980; Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге. К., 1999; Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006.

*Р.Х.Мөхиярова.*

**СИ́НТАКСИС** (грек. sýntaxis — төзелеш, тәртип), 1) аерым телләргә хас булган сөйләм берәмлекләрен төзүче чаралар һәм кагыйдәләр. Татар телендә синтаксик бәйләнеш чаралары булып *аффикслар* (килеш, зат һәм сан кушымчалары), бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр, *теркәгечләр* һәм теркәгеч сүзләр, мөнәсәбәтле сүзләр, *интонация*, сүз тәртибе тора. 2) *Грамматиканың* тел системасының бу өлешен өйрәнүче тармагы. Фән буларак, С. синтаксик берәмлекләр төзелешен аларны сөйләмдә кулланганда килеп чыга торган үзенчәлекләре б-н бергә өйрәнә. Татар теле С.ы өч төп өлештән тора. Үз эченә *сүзтезмә* С.ын да алучы гади *җөмлә* С.ы сөйләм оешкан вакытта аерым җөмләләр барлыкка китерүче билгеле бер җөмлә калыпларын, аларның гамәлгә ашу юлларын, төрле төшенчәләр б-н таралыш алуын өйрәнә, шул максаттан сүз төркемнәренең үзара ярашу кагыйдәләрен, җөмлә составында булган сүзтезмәләрдәге сүзләр арасында теге яки бу семантик-грамматик мөнәсәбәтләр вакытында бәйләнеш барлыкка китерүче чараларны билгели; фикерне җиткерү дәрәҗәсеннән чыгып, җөмлә кисәкләренең урнашу тәртибен, җөмләнең текстка ярашу кагыйдәләрен өйрәнә. Кушма җөмлә

С.ы мөстәкыйль булмаган берничә җөмләдән торган җөмлә калыпларын, теге яки бу семантик мөнәсәбәттәге катлаулы җөмлә өлешләрен үзара бәйләүче чараларны, катлаулы кушма җөмләнең структур үзенчәлекләрен өйрәнә. Текст С.ы кушма синтаксик бөтеннәр, ш.у. гади һәм кушма җөмләләрдән торган текст төзү кагыйдәләрен, текстның мәгънәви, структур, композицион, грамматик бәтенлеген һ.б.ны өйрәнә. Фән буларак татар теле С.ы 18 йөздән үсеш ала башлый. 19–20 йөзләрдә А.А.Троянский, М.И.Иванов, М.К.Казимбәк, К.Насыйри, Ш.Иманаев, Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди, М.Х.Корбангалиев, Г.Алпаров һ.б.ның хезмәтләре дөнья күрә. Озак еллар дәвамында телчеләр сүтезмәләр һәм җөмләләрне аларның сөйләмдә кулланылыш үзенчәлекләрен исәпкә алмый гына, ягъни язма текст дәрәҗәсендә генә өйрәнү б-н чикләнәләр. 1950 еллар ахырында татар С.ы телнең сөйләм төзелешен һәм сөйләм барлыкка килү кагыйдәләрен өйрәнә башлый. Татар теле С.ы мәсьәләләре В.Н.Хангилдин, Ф.С.Сафиуллина, С.М.Ибраһимов, К.З.Зиннәтуллина, М.З.Зәкиев һ.б.ның хезмәтләрендә яктыртыла.

*Әд.:* Хангилдин В.Н. Татар теле грамматикасы. К., 1959; Зәкиев М.З. Татар грамматикасы: Синтаксис. М.–К., 1999. Т. 3; шул ук. Татар синтаксисы. К., 2008; шул ук. Синтаксический строй татарского языка. К., 1963; Сафиуллина Ф.С. Синтаксис татарской разговорной речи. К., 1978.

*М.З.Зәкиев.*

**СИНТӘ́К** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 44 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Питиал елгасы буенда. 2010 елда 26 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — яшелчәчелек. 1613–16 лардан Сәйтәк буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Күлбаш, Кече Синтәк исемнәре б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, башмак тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 224,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кавал волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 25 ир-ат; 1859 да — 114, 1897 дә — 192, 1908 дә — 242, 1920 дә — 207, 1926 да — 277, 1938 дә — 264, 1949 да — 200, 1958 дә — 127, 1970 тә — 159, 1979 да — 98, 1989 да — 53, 2002 дә — 42 кеше.

**«СИ́НТЕЗ»**, суда туплы уен командасы, «Казаноргсинтез» АҖ каршында 1974 елда оештырыла. 1975–92 дә СССР (РФ) чемпионатының 1 нче лигасында, 1993 тән Россия чемпионатының югары лигасында. РСФСР чемпионатында көмеш медаль ала (1977), бөтенроссия яшьләр уеннарында җиңүче (1977, 1981), РСФСР (1980, 1985, 1989), Россия (2006/07) чемпионы, Россия Кубогы (2005), «Лен-Трофи» Европа Кубогы (2006/07) иясе, Россия чемпионатында (2005/06, 2007/08) көмеш медаль, Россия Кубогында (2009), Россия чемпионатында (2004/05, 2008/09) бронза приз ала. Баш тренерлары — В.А.*Лелюх* (1974–95), Е.Н.Мишин (1995–2002), Р.Д.Юмаев (2002–04), В.Н.Захаров (2004–11), И.Х.Зиннуров (2011–2014), В.А.Федорин (2014 тән). СССР, Россия, бөтенсоюз, бөтенроссия һәм халыкара турнирларда, Олимпия уеннарында катнашучылар — А.Бойко, Д.Вахромеев, О.Владимиров, И.Н.Горбач, М.С.Закиров, И.Х.Зиннуров, А.Остробоков, А.Черных, Н.И.Шәрәфиев, Р.Д.Юмаев, В.Л.Яковлев. Клубның аренасы — «Оргсинтез» йөзү бассейны.

*Әд.:* Шамсутдинов А.С., Камешков А.А. Водное поло тысячелетнего города: История водного поло г.Казани в документах, таблицах, воспоминаниях и фотографиях. К., 2004.

**СИНУГЫ́Л** (Синугылов) Әдхәт Мәкәрим улы (15.3.1935, БАССРның Эстәрлебаш р-ны Куганакбаш а. — 14.1.2004, Казан, туган авылында җирләнә), шагыйрь, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1995). Казан ун-тын (1964), А.М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1985) тәмамлый. Татарстан китап нәшриятында мөхәррир (1967–71), ТР Дәүләт филармониясендә әдәби бүлек мөдире (1971–77) вазифаларын башкара. 1977 дән Ташкентта яши: «Үзбәкфильм» киностудиясендә өлкән мөхәррир, Бөтендөнья авторлар хокуклары ассоциациясенең Үзбәкстан Респ-касы буенча вәкаләтле вәкиле, 1979 дан «Йолдыз» кырым-татар ж-лында әдәби хезмәткәр. 1980–90 елларда «Ватаным Татарстан» г-тасының, «Татар-информ» агентлыгының һәм Үзәк Азиядәге БДБ илләре буенча «Азатлык» радиостанциясенең үзхәбәрчесе. 1988 дән Симферополь шәһәрендә яши. «Чалгы җыры» (1977), «Яшьлек һәйкәле» (Таш., 1979), «Җыр төбәгән сагынып» (1984), «Каракаш» (Таш., 1989), «Көньяк гөлләре» (1990), «Иман гасыры» (2002), «Ефәк кәрваннары» (2002) шигырь җыентыклары, «Ник елыйсың, курчагым?» (2000), «Урал кунагы» (Уфа, 2002) балалар китаплары авторы. С.ның төрле географик җирлектә туган шигырьләре шул төбәкләр б-н тыгыз бәйләнеше, туганлык мөнәсәбәтләре, татар халкына, аның теленә һәм какшамас рухына ихтирамы турында сөйли. Иҗатына классик шәрекъ шигъриятенең йогынтысы зур. Тәрҗемә өлкәсендә дә хезмәтләре күп. Татар әдәби теленә Й.Баласагуниның «Котадгу белек» поэмасыннан өзекләрне, Әбүгалисина, Галишер Нәваи, Хафиз, Сәгъди, Р.Гамзатовларның шигырь һәм поэмаларын тәрҗемә итә.

*Әд.:* Миңнегулов Х. Мәхәббәт һәм нәфрәт шагыйре // Гасырлар өнен тыңлап... К., 2003; Писатели Советского Узбекистана. Таш., 1984.

*Г.М.Габделхакова.*

**СИНЦО́В** Евгений Васильевич (14.12.1955, Свердловск өлкәсенең Серов ш.), философ, филол. фән. канд. (1984), филос. фән. д-ры (1996), проф. (1998). Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлый (1980). 1984 елдан Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында эшли. 2003 тән Казан энергетика ун-тында, татар һәм рус телләре каф. мөдире, бер үк вакытта, 1996–2001 дә, «Прометей» экспериментал эстетика фәнни-тикшеренү ин-тының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.



Ә.Г.Синяева.



О.Г.Синяшин.

Хезмәтләре сәнгатьлелекнең процессуаль-синергетик аспектларына, сәнгать һәм мәдәниятнең орнаменталь-пластик нигезләренә карый.

Хезм.: Рождение художественной целостности. К., 1995; Природа невыразимого в природе и искусстве: К проблеме жёсто-пластических оснований художественного мышления в визуальной орнаментике и музыке. К., 2003; В поисках ненаписанного романа: горизонт возможностей обновления жанров в творчестве А.С.Пушкина. К., 2006.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. 2004. Т. 3.

**СИНЦО́В** Иван Фёдорович (30.3.1845, Могилёв губ. — 9.7.1914, С.-Петербург), геолог, геогнозия д-ры (1872), проф. (1873). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1868), шунда ук укыта, бер үк вакытта, 1870 елдан, геол. кабинеты саклаучы-хезмәткәре. 1871 елдан Новороссийск ун-тында. 1900 дән Финанс министрлыгының махсус йөкләмәләр чиновнигы. Хезмәтләре Россия геологиясенә һәм гидрогеологиясенә карый. С. Казан губ. терр-ясендә мезозой утырмаларын беренче булып җентекләп өйрәнә.

*Әд.:* 50 лет со дня смерти И.Ф.Синцова // Советская геология. 1965. № 1.

**СИНЯ́ЕВА** (Синәева; чын фамилиясе Халитова) Әшрәф Гатаулла кызы (1892, Рязань губ. Касыйм ш. — 30.3.1925, Ленинград ш.), драма актрисасы. С.-Петербургта Александра театры каршындагы студияне тәмамлый. 1917 елның сентябрендә Казанда «Сәйяр» труппасына керә. 1917–18 елгы сезонда Галиябану (М.Фәйзинең шул исем. әсәре буенча), Зөһрә («Таһир-Зөһрә», Ф.Бурнаш), Биби («Назлы кияү», К.Тинчурин), Елена («Мещаннар», М.Горький), Аня («Чия бакчасы», А.П.Чехов) рольләрен зур уңыш б-н башкара. 1918–20 дә С. мөселман хәрби комис-ты каршындагы татар театр труппасы составында эшли. 1920–21 дә Беренче татар дәүләт драма труппасында, анда Рокыя («Тигезсезләр», Ф.Әмирхан), Марья Антоновна («Ревизор», Н.В.Гоголь) рольләрен башкара.

*Әд.:* Татар театры (1906–1926). К., 2003; Иллялова И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; Арсланов М.Г. Татарское режиссёрское искусство. 1906–1941. К., 1992.

**СИНЯ́ШИН** Олег Герольдович (25.2.1956, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1990), РФА академигы (2006; 1997 дән мөхбир әгъза), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2006). Казан ун-тын тәмамлый (1978). РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли, металлорганик синтез лаб-ясе мөди-

ре (1996 дан), директор урынбасары (1996–2001), директор (2001 дән), бер үк вакытта Казан технол. ун-тының органик химия каф. мөдире (2001 дән), проф. (2001). РФА-нең Органик һәм элементорганик химия буенча фәнни советы рәисе урынбасары (2000 нән), РФА КГҮ рәисе (2008 дән). Хезмәтләре элементорганик һәм координацион кушылмалар химиясенә, электрохимик синтезга, фуллерен кушылмаларына һәм наноматериалларга карый. С. органик һәм металлорганик кушылмаларны өч валентлы фосфор к-тасы тиокушылмалары катнашында фосфориллау һәм тиилирлауның гомуми алымнарын эшли. Фосфорорганик кушылмалар – тиолофосфогидридлар классын ача һәм өйрәнә; ирекле радикаллы лигандалы цимантрен рәтеннән ике төшле һәм оптик актив 17 электронлы күкертле тотрыклы комплекслар синтезлый. Функциональ алыштырылган катлаулы гетероциклик һәм каркаслы фосфин лигандларын конструкцияләү стратегиясен тәкъдим итә, супрамолекуляр химия өчен оригиналь объектлар – элек билгеле булмаган макроциклик фосфиннарның үзлегеннән җыелуы күренешен ачыклый. Органик һәм металлорганик кушылмалар тәэсирендә элементар (ак) фосфорның химик һәм электрохимик активлашуы, ш.у. трансформациясе процессларын өйрәнүгә караган фәнни юнәлешне үстерә. Фуллереннарның органик химиясенә зур өлеш кертә. Уйлап табуга 15 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007).

Х е з м.: Тиопроизводные кислот трёхвалентного фосфора. М., 1990 (автордаш); Электрохимия фосфорорганических соединений // Электрохимия органических соединений в начале XXI века. М., 2008 (автордаш); Активация и трансформация молекулы белого фосфора под действием комплексов палладия (II) // Изв. РАН. Сер. химическая. 2010 № 6 (автордаш.); Кафедра органической химии – колыбель и кузница кадров научной школы фосфороргаников КГТУ (КХТИ). К., 2010 (автордаш.); Фосфолиды щелочных металлов // Успехи химии. 2014. Т. 83, № 6 (автордаш).

**СИҢГЕ́Л** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 53 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 231 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле – мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. Рус чыганакларында 1565–68 дән Сенгиль буларак мәгълүм. 18 йөздә – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиyннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1406,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Саралан волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән – Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән – Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә – 56 ир-ат; 1859 да – 508, 1897 дә – 1105, 1908 дә – 1306, 1920 дә – 1335, 1926 да – 1437, 1938 дә – 1301, 1949 да – 698, 1958 дә – 686, 1970 тә – 524, 1979 да – 420, 1989 да – 335, 2002 дә – 237 кеше.

**СИПСА́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Ушма елгасының (Вятка елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 12,7 *км*, бассейнының мәйданы 47,4 $км^2$. Мамадыш р-нында ага. Елга башы Максим Пүчинкәсе авылыннан 5 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Красная Горка авылында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы – 55 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. С.ның 0,7 дән 4,7 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,52 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 143 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,07 $м^3/с$. Язын суы йомшак (1–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**СИРА́ЕВ** Марат Әшрәф улы (1.1.1936, Әлки р-ны Урта Әлки а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1982). Казан а.х. ин-тын (1964), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1971) тәмамлый. 1960–61 елларда хезмәт иялəре депутатларының Әлки р-ны советы бүлеге мөдире, 1971–76 да – Апас р-н советы башкарма ком-ты рәисе. 1963–65 тә Куйбышев р-ны «Пичкасский» с-зының партком секретаре, 1965–67 дә Алексеев р-ны «Разумовский» с-зы директоры. 1967–69 да КПССның Алексеев р-ны ком-ты секретаре. 1976–83 тә ТАССР а.х. министрының 1 нче урынбасары. Бер үк вакытта, 1979–83 тә, колхоз һәм совхозларга агрохимик хезмәт күрсәтү буенча Татарстан респ-ка ФҖБ башлыгы. 1983–85 тә ТАССР а.х. министры. 1985–88 дә ТАССР Агросәнәгать ком-ты рәисенең 1 нче урынбасары. 1988–90 да Татарстан респ-ка стат. идарәсе башлыгы. 1990–94 тә ТР Дәүләт (парламент) контроле ком-ты рәисе, 1994–99 да – ТР Үзәк сайлау комиссиясе рәисе. 1999–2008 дә «Казан Кремле» тарих-архит-ра һәм сәнгать музей-саклаулыгы директорының 1 нче урынбасары. 1983–90 да ТАССР, 1990–92 дә – ТССР, 1992–95 тә – ТР ЮСлары депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**СИРА́ЕВ** Мәгъсүм Шәрәфи улы (1908, Сембер губ., Буа өязе Үби а. – 1959 елдан соң), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. 1925–26 да ВЛКСМның Ижевск шәһәренең Завод р-н ком-ты инструкторы. 1926–27 дә Воткинск шәһәре балалар йорты мөдире (Вотяк автономияле өлкәсе). 1932–33 тә Казан постау ф-касында бүлек мөдире. 1933–39 да «Красный текстильщик» Кукмара киез итек ф-касында бүлек мөдире, цех башлыгы, баш инженер урынбасары, 1939–43 тә баш инженер. 1943–47 тә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты бүлек мөдире урынбасары. 1947–48 дә ВКП(б)ның Казан шәһәр ком-ты секретаре урынбасары. 1948–59 да ТАССР җирле сәнәгать министры. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**СИРАҖЕТДИ́НОВ** Абдулла Минһаҗ улы (16.11.1912, хәзер Пермь өлкәсенең Чусовой ш. – 11.10.1986, Алма-Ата), тау эшләре инженеры, техник фән. д-ры (1970), проф. (1971). 1939 елда Свердловск тау эшләре ин-тын тәмамлый. 1939–41 дә Лениногорск руднигында участок башлыгы, баш инженер, башлык, 1941–44 тә Сокольный руднигы башлыгы, 1945–46 да Белоусов руда идарәсе директоры, 1946–50 дә Ачисайск полиметалл комб-тының (Көнчыгыш Казакъстан өлкәсе) баш инженеры, директор урынбасары. 1950–57 дә СССР Госгортехнадзорының Казакъстан тау эшләре округы башлыгы (Алма-Ата). 1957–59 да Көнчыгыш Казакъстан ХХС рәисенең 1 нче урынбасары (Усть-Каменогорск ш.). 1959–65 тә Казакъстан ССР МСның фәнни-тикшеренү эшләрен координацияләү буенча Дәүләт ком-ты рәисе. 1965 тән Казакъстан ССР ФАнең Тау эшләре ин-тында, директор вазифаларын башкаручы (1965–68), директор (1968–71), лаб. мөдире (1969–84), фәнни киңәшче (1984–86). Хезмәтләре җир асты байлыкларын комплекслы үзләштерү мәсьәләләренә һәм рудалы чыганакларны эшкәртүгә карый. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Основные показатели промышленных кондиций на руды цветных металлов. А.-А., 1973; Рациональное использование руд на месторождениях цветных металлов Казахстана. А.-А., 1976 (автордаш); Теория и практика комплексного освоения месторождений цветных металлов Казахстана. А.-А., 1986 (автордаш).

**СИРАҖЕТДИ́НОВ** Дуглас Зыя улы (19.2.1934, Актүбә ш. – 25.7.1994, Алма-Ата), химик-технолог, техник фән. д-ры (1984), проф. (1987). Казакъстан ун-тын (1956) һәм Алма-Ата патентлар һәм уйлап табу эшләре ун-тын (1966) тәмамлый. 1956 елдан Казакъстан ССР ФАнең Химия фәннәре ин-тында, фосфорлы ашламалар химиясе лаб-ясе мөдире (1974 тән) һәм директор урынбасары (1989–94). Хезмәтләре катнаш кислоталы-термик процессларның физика-химиясенә карый. С. фосфатлар б-н силикатлар, сульфатлар, боратларны, ш.у. минерал һәм фосфат чималын катнаш кислоталы-термик эшкәрткәндә хасил булган системалардагы башка компонентларны бергә полимерлаштыру продуктлары нигезендә юнәлешле рәвештә полифосфатлар, нәорганик полимерлар синтезлый. Фосфорлы ашламаларның яңа – туфракка үсемлекләр өчен файдалы элементларның аерылып чыгуы көйләнелә торган буынын уйлап чыгара. Металлны кисеп эшкәртү өчен нәорганик майлау материаллары, медицинада куллану өчен организмнан үзеннән-үзе таркалып чыга торган бер-берсенә туры килүче биол. состав композитлары тәкъдим итә. Полимер ашламаларның С. эшләгән технологияләре – БДБ илләренең фосфат з-дларында, майлау-суыту сыекчаларын табу процесслары Караганда

металлургия комб-тында җитештерүгә кертелгән. Уйлап табуга 55 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсы медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Физико-химические основы получения полифосфатных удобрений. А.-А., 1979 (автордаш); Химия и технология плавленых фосфатов. А.-А., 1989 (автордаш).

**СИРАҖЕТДИ́НОВ** Марат Фәрит улы (24.9.1948, Уфа ш.), пианист, педагог, ТРның халык артисты (2009). 1971 елда Мәскәү консерваториясен (А.Наседкин классы) тәмамлый. 1971–87 дә Казан консерваториясендә укыта, 1988–92 дә Татар филармониясендә, бер үк вакытта Башкорт филармониясендә артист, 1992–96 да — Казан пед. ун-тының музыка-пед. ф-тында, 1997–2006 да — 18 нче балалар сәнгать мәктәбендә, 2006 дан Казанның Кече музыка сәнгате академиясендә укыта. С. соло концерт программалары б-н чыгышлар ясый, симф. оркестрларда солист, концертмейстер һәм ансамблист булып эшли. Аеруча Татарстан (Н.Җиһанов, Р.Яхин, Ф.Әхмәтовның фортепиано әсәрләрен беренче башкаручы) һәм Идел буе республикалары (Ф.Лукин, В.Асламас, В.Ходяшев (Чуаш Респ-касы), В.Кульшетов, В.Алексеев, А.Незнакин (Мари Респ-касы), Р.Газизов, М.Әхмәтов, Р.Хәсәнов (Башкортстан Респ-касы) һ.б.) композиторларының фортепиано музыкасын пропагандалауга зур игътибар бирә. Шулай ук чит илләрдә (Белоруссия Респ-касы, Болгария, Төркия, Финляндия, Көньяк Корея, АКШ һ.б.) концертлар куя. «Европа-Азия», «Россия музыкасы панорамасы» («Панорама музыки России») фестивальләрендә, Татарстанның әйдәп баручы композиторларының юбилей концертларында һәрдаим катнаша. С.ның иҗади йөзен билгеләүче сыйфатлар: югары профессионализм, башкару культурасы, төрле чорларга һәм жанрларга караган әсәрләрне үз эченә алучы бай репертуар, стильне нечкә тоемлау, фортепиано өчен язылган әсәрләрнең дәлилле интерпретацияләре. С. актив концерт эшчәнлеген пед. һәм муз.-мәгърифәтчелек эшчәнлеге б-н уңышлы аралаштыра. Яшь музыкантларның иҗади үсешенә булышлык итә, аның җитәкчелегендәге башкаручылар конкурсларда лауреат (М.Маликов, Р.Ефремов, Н.Сәхәбиев һ.б.) булалар.

**СИРАҖЕТДИ́НОВ** Морат Нур улы (29.4.1950, Көнчыгыш Казакъстан өлкәсе Курчум р-ны Маралиха а.), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1992), проф. (1993), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2002). 1972 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында эшли. 1983 тән Кама политехник ин-тында (Чаллы ш.), автомобиль конструкцияләренең динамикасы һәм ныклыгы каф. мөдире (1992 дән). 2001 дән Казан техник ун-тының теоретик механика һәм материаллар каршылыгы каф. мөдире. Хезмәтләре деформацияләнә торган каты җисем механикасына карый. С. хәрәкәт итә торган деформацияләнүчән конструкцияле җисемнәрнең үзара тәэсир итешүенең матем. модельләрен һәм аларны исәпләү методикасын, катлаулы геометрияле юка тышчалы конструкцияләрнең статик һәм динамик деформациясен вариатив исәпләү алымын эшли; локаль дефектлары булган көпшәләр һәм аппаратлардан файдалануның мөмкин табылган шартларын билгеләү критерийларын тәкъдим итә.

Х е з м.: Расчёт упругих тонкостенных конструкций сложной геометрии. К., 1993 (автордаш); Теория и конечные элементы для расчёта тонкостенных конструкций сложной геометрии // Вестн. Нижегор. ун-та. Сер. Механика. 2000. Вып. 2 (автордаш).


М.Ф. Сиражетдинов.


Т.К. Сиражетдинов.


Т.Г. Сиражетдинов.

**СИРАҖЕТДИ́НОВ** Рифкат Тәлгат улы (22.10.1957, Казан), идарә итү теориясе белгече, техник фән. д-ры (1998). 1980 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, процесслар динамикасы һәм идарә итү каф. мөдире (1998 дән). Хезмәтләре аныксызлык шартларында катлаулы системаларны модельләштерү һәм алар б-н идарә итү өлкәсенә; күп критерийлы оптимальләштерүнең санлы алымнарын эшләүгә, төбәк икътисадын, инновация процессларын, тәвәккәллекне матем.-икътисади динамик модельләштерүгә һәм алар б-н идарә итүгә карый. С. күп критерийлы мәсьәләләрне санлы чишү алымын; идарә объектының параметрлары аныксыз булганда сызыкча системаларның траектория ансамбльләрен һәм характерлы полином тамырлары урнашкан өлкәләрне төзү алымнарын; космик аппаратлар системасы өчен мөмкин табылган күчеш өлкәләрен төзү алымнарын тәкъдим итә.

Х е з м.: Построение гарантированной области расположения нулей и полюсов передаточных функций динамических систем // Автоматика и телемеханика. 1988. № 7; Математическое моделирование мощности инфраструктуры сложных систем // Изв. РАН. Теория и системы управления. 1998. № 3; Динамическое моделирование экономики региона. К., 2005 (автордаш).

**СИРАҖЕТДИ́НОВ** Тәлгат Касыйм улы (13.11.1927, Арча кантоны Сауыш а. – 3.1.2016, Казан; Теләче р-ны Сауыш авылында җирләнә), механика, идарә итү теориясе, матем. модельләштерү өлкәсе белгече, техник фән. д-ры (1967), ТР ФА академигы (1993), ТАССРның һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1970, 1982). 1950 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, очыш динамикасы һәм идарә итү каф. мөдире (1967–91), проф. (1968), проректор (1978–84), идарә итү һәм эшмәкәрлек ф-ты деканы (1991–92), идарә итү, маркетинг һәм эшмәкәрлек каф. мөдире (1991–99), шул ук каф. профессоры (1999 дан).

Хезмәтләре бүленгән параметрлы системаларны оптимальләштерүгә, алар б-н идарә итү теориясенә һәм аларның тотрыклылыгына, күп критерийлы һәм күп режимлы катлаулы системалар модельләштерүгә һәм аналитик проектлаштыруга карый. С. сыеклык ягалап ага торган оптималь формалы җисемнәр төзү өчен газ динамикасының вариатив мәсьәләләрен хәл итүгә (Гудерлей-Армитейдж-Сираҗетдинов алымы), җисем йота торган җылылык агымын минимальләштерүгә һ.б. өр-яңа алымнар тәкъдим итә. Ляпунов функцияләре алымын процесслар күплеген тотрыклылыкка тикшерүдә куллану мөмкинлеге бирә торган махсус үлчәм (С. үлчәме) кертә. Төрле катлаулы системалар (очкыч аппаратларның вертикаль утырту җайланмалары һәм канатлары) проектлауны автоматлаштыруда, ш.у. пилотсыз объектларның параметрларын сайлап алуда кулланыла торган алым — катлаулы объектлар б-н идарә итү һәм аларны проектлау синтезы мәсьәләсен чишү алымын (идарә итүнең һәм аналитик проектлаштыруның төп мәсьәләсе) эшли. С. идарәне оештыру һәм автоматлаштырылган фаразлау һәм планлы исәп-хисап системасын булдыру максатында пр-тие һәм халык хуҗалыгы модельләрен төзүдә катнаша (СССР Электроника сәнәгате министрлыгында гамәлгә кертелә). Динамик системаларның тотрыклылыгы һәм алар б-н идарә итү мәсьәләләре буенча лекцияләр уку һәм тикшеренүләр үткәрү өчен күп тапкырлар Кытай һәм Бразилия югары уку йортларына чакырыла. Почёт, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары; медальләр, ш.и. РФ Космонавтика федерациясенең Ю.А.Гагарин исем. медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Оптимизация систем с распределёнными параметрами. М., 1977; Устойчивость систем с распределёнными параметрами. Новосиб., 1987; Динамическое моделирование экономики региона. К., 2005 (автордаш).

**СИРАҖЕТДИ́НОВ** Тимур Гали улы (20.1.1969, Ленинград, хәзер С.-Петербург ш. — 10.3.2000, шунда ук), РФ Герое (29.8.2000, үлгәннән соң), эчке хезмәтләр капитаны. Ленинград тимер юл гаскәрләре югары хәрби уч-щесен тәмамлый (1987). 1990 елда СССР Кораллы көчләреннән китә. 1990–92 дә Кече пр-тиеләр ассоциациясендә инженер булып эшли (Ленинград). 1993–2000 дә С.-Петербург һәм Ленинград өлкәсе буенча РФ Юстиция министрлыгының җәзалар башкару Баш идарәсе «Тайфун» махсус бүлегенең уку-укыту бүлекчәсе инструктор-методисты. 1995–2000 елларда Чечен Респ-касы терр-ясендә законсыз оешкан кораллы төркемнәрне юк иткәндә батырлык күрсәтә; С. куйган миналардан бу төркемнәрнең 8 кешесе һәлак була. Гранатомёттан

атып дошманның пулемёт расчётын юк итә, засадага эләккән подразделениене коткара, Комсомольское авылы (Чечен Респ-касы) янындагы сугышта каршы якның 5 сугышчысын юк итә. Отряд командирының гомерен саклап һәлак була. Ике Батырлык ордены һәм медаль б-н бүләкләнә. С.-Петербургның С. укыган 534 нче урта мәктәп бинасына мемориаль такта куела.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СИРАҖИ́ЕВ** Дамир (чын исеме Раид) Равил улы (17.9.1954, Кайбыч р-ны Зур Подберезье а. — 17.12.1998, Казан), актёр, режиссёр. Казан театр уч-щесен (1974), Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тының режиссёрлык ф-тын (1980, Ю.А.Завадский курсы) тәмамлый. 1980 елда Татар акад. театры сәхнәсендә «Кияү белән кәләш» (Х.Вахит пьесасы буенча) диплом спектаклен куя. 1980–81 дә Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) режиссёры, анда тамашачыны уен һәм импровизация атмосферасына җәлеп иткән «Беркем дә ышанмас» («Никто не поверит», Г.И.Полонский), «Мальчиш-Кибальчиш вакыйгасы» («История Мальчиша-Кибальчиша», В.К.Железников; А.П.Гайдар хикәяләре буенча) спектакльләрен куя. 1981–88 еллар дәвамында С. Татар акад. театры сәхнәсендә 9 спектакль куя, алар арасында Ю.Сафиуллинның «Алмазбулат» әкияте (1981), И.Юзеевның «Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз» комедиясе (1983), К.Хоинскийның «Җәһәннәм биюе» («Ночной гость»), А.Гыйләҗевнең «Көйсезләнгән сәфәр» (икесе дә — 1988) әсәрләре буенча да спектакльләр бар. Ч.Айтматовның «Ахырзаман» романы буенча куелган спектакль (1987) киң иҗтимагый яңгыраш ала. Әлеге спектакльдә әсәрнең фәлсәфи тирәнлеген эпик театр чаралары ярдәмендә истә калырлык сәнгати формада ачу омтылышы күзәтелә. 1989–90 да С. — Татар драма һәм комедия театрының баш режиссёры. Анда ул «Ике килен-килендәш» (Х.Вахит), «Галиябану» (М.Фәйзи), «Аршин мал алан» (У.Хаҗибәков), «И машина, машина, җитте минем башыма» (Р.Вәлиев) спектакльләрен куя. Композитор М.Шәмсетдинова б-н берлектә Казанның Үзәк стадионында театральләштерелгән «Болгар дастаны» («Болгарский дастан», 1989) һәм Казан Кремлендә «Сөембикә турында риваять» («Сказание о Сююмбике», 1991) тамашаларын гамәлгә ашыра. С. Минзәлә татар драма театрында («Упкын читендә» («Порог»), А.А.Дударев, 1983; «Сөрелгән фәрештәләр» («Звёзды на утреннем небе»), А.М.Галин, 1988), Бөгелмә рус драма театрында («Физиклар» («Физики»), Ф.Дюрренматт, 1983), Казан театр уч-щесендә («Сычуаньнан килгән мәрхәмәтле кеше» («Добрый человек из Сычуани»), Б.Брехт) спектакльләрен куя. С.нең котелмәгән чишелешләр, кыю фикерләр, бай фантазия б-н аерылып торган спектакльләре Казанның театр тарихында сизелерлек эз калдыра. 1991 дән иҗтимагый эшчәнлек һәм кәсәбәчелек б-н шөгыльләнә. 1999 да Татар акад. театры тарафыннан, татар театр сәнгатенә лаеклы өлеш керткән өчен, С. исемендә ел саен бирелә торган бүләк булдырыла.

*Әд.:* Сафиуллин Ю. Чәчәкләр һәм күз яшьләре. К., 1999; Дамир Сиражиев = Damir Siraciev: Истәлекләр һәм мәкаләләр җыентыгы. К., 2009.

**СИРА́Й** (Сираев) Дифгат Шәмси улы (20.12.1933, Бондюг, хәзер Менделеев р-ны Камай а. — 20.6.1985, Казан, туган авылында җирләнә), шагыйрь. Алабуга пед. ин-тын (1964), Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1972) тәмамлый. 1965–72 елларда «Хезмәт» Балтач район г-тасында җаваплы сәркәтип, соңрак мөхәррир. 1974–85 тән «Социалистик Татарстан» г-тасында бүлек мөхәррире һәм бүлек мөдире. Әсәрләре 1950 еллар ахырында басыла башлый. «Таң сызыла» (1967), «Саумы, тормыш» (1968), «Кушнарат» (1969), «Кыяларга үзем менәм» (1972), «Мәхәббәтем» (1983), «Үзәннәрдә калам» (2004) шигырь җыентыклары авторы. «Кеше турында җыр» (1974), «Каентүбә» (1974), «Авыл поэмасы» (1974), «Әманәт дәфтәре» (1979), «Минем анкетам» (1980) кебек үзенчәлекле поэмаларында романтик рух, әйдәүче пафос өстенлек итә. Шигырьләренә үткенлек, җорлык, публицистик яңгыраш хас. Әсәрләрендә чагылдырылган төп тема — татар авылы һәм аның кешеләре. С.ның кайбер шигырьләре композиторлар Ә.Бакиров, З.Гыйбадуллин тарафыннан көйгә салына. Юмористик әсәрләре «Тәрәзәгә чиртер мизгел» (1986) дигән күмәк җыентыкта урын алган.

*Г.М.Габделхакова.*

**СИРА́Т** (гарәп. سيرة — юл), дини төшенчә; Коръәндә «туры юл» (хак юл) мәгънәсендә кулланыла. Мөселман әдәбиятында С. башкача — һәр кешегә, вафат булганнан соң, утлы упкын өстеннән сузылган «кылдан нечкә, кылычтан үткен» сират күпере аша чыгасы бар дип тә аңлатыла. Сөнниләр фикеренчә, хак мөселманнар әлеге күперне үтеп чыгалар, ә гөнаһлылар җәһәннәм утына егылып төшәләр. Шигыйлар фикеренчә, Кыямәт көнендә күпер янында Мөхәммәд пәйгамбәр б-н бергә Гали пәйгамбәр дә булачак һәм җәннәткә аннан рөхсәт алганнар гына керәчәк. Мөселман күзаллаулары буенча, Корбан бәйрәмендә чалынган хайван корбан чалган кешене күпер янында көтеп торачак һәм күпер аша алып чыгачак.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**СИРЕ́НИЯ** (Syrenia), әвернә чәчәклеләр семьялыгыннан икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 15 кә якын төре билгеле. Евразиядә таралганнар. Татарстан терр-ясендә 2 төре — чал С. (S. cana) һәм тау С.се (S. montana) Көнчыгыш Кама аръягында очрый. Ташлы тау битләрендә үсәләр. 20–90 *см* биеклектәге үсемлек. Үзәк тамырлы. Сабагы туры, тармаклы, төкчәле. Яфраклары чиратлашкан, кыяк (тау С.се) һәм тар кыяк (чал С.). Чәчәкләре ачык сары, дөрес формада, озын чукларда. Җимешләре — сабакка сарылган кыска саплардагы 4 кырлы кузак. Июнь–июльдә чәчәк аталар. Җимешләре июль–августта өлгерә. 2 төре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**СИРЕ́НЬ**, канәфер куагы (Syringa), зәйтүнчәләр семьялыгыннан яфрак коючан куак яки зур булмаган агачлар ыругы. 30 га якын төре билгеле, Евразиядә очрыйлар. Татарстан терр-ясендә гади С. (S. vulgaris) үстерелә. 3–7 *м* биеклектәге куак. Тамыр системасы җир өслегенә якын, чук. Сабагы һәм ботаклары соры шома кабыклы. Яфраклары каршыдаш, куе яшел, ялтыравыклы, очлары сузынкы. Чәчәкләре 4 таҗ яфраклы, көпшәсыман таҗлы, аксыл шәмәхә яки ак, хуш исле, куе пирамидасыман себеркәчкә җыйналган. Җимеше — ачык күрән орлыклы итчел



Гади сирень.

тартмачык. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре июльдә өлгерә. Вегетатив юл б-н (тамыр үрентеләреннән һәм үсентеләрдән) үрчи. Чәчәк һәм яфракларында алкалоид, аминокислоталар, эфир мае, органик к-талар бар. Халык медицинасында ялкынсынуга каршы, тир чыгару, авыртуны басу һәм яра төзәтү чарасы буларак кулланыла. Бакча һәм торак пунктларда декоратив үсемлек буларак, ш.у. венгр С.е (S. josikaea) үстерелә.

**СИРИ́Н** (псевд., чын фамилиясе Батыршин) Сирин Хәниф улы (14.12.1896, Самара губ., Бөгелмә өязе Кәрәкәшле а. — 23.11.1969, шунда ук), шагыйрь. Бәйрәкә мәдрәсәсендә белем алганнан соң, Кәрәкәшле, Азнакай, Әсәй авылларында башлангыч мәктәпләрдә укыта. Бөгелмәдә укытучылар курсларында (1918–20) укый. Беренче шигырьләрен «Якты юл» җирле г-тасында бастыра. 1921 елдан Казанда яши. Шәрекъ пед. ин-тын тәмамлый (1931), Казан мәктәпләрендә укыта. «Кеше» (1930), «Тамчылар» (1931), «Корыч атлар» (1931), «Шигырьләр» (1959) шигъри җыентыклары авторы. С. — нечкә лирик, туган як табигате җырчысы; иҗатында социаль тематика да урын ала. 1935 тә советларга каршы пропагандада гаепләнә, 5 елга ирегеннән мәхрүм ителә; 1957 дә аклана. Физик һәм мораль яктан сынып кайтканнан соң, иҗаттан китә. Бөек Ватан сугышында катнаша, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Мостафин Р. «Кыш сайрамый сандугач...» // Казан утлары. 1996. № 12.

**СИРМА́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Тимерлек елгасының (Олы Чирмешән елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 10,8 *км*, бассейнының мәйданы 43,1 *км*². Идел аръягы түбәнлеге буйлап, Нурлат р-нында ага. Елга башы урман массивында Әлмәт р-ны б-н Беренче Май урманы чигендә, Ака посёлогыннан (даими яшәүчеләр юк) 5 *км* көнбатыштарак; тамагы Петровский посёлогыннан көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 132 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. Су җыелу

мәйданының урманлылыгы 65%. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,25 *км/км*². Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 79 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,03 *м³/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**СИРМА́ТОВ** Индус Фатих улы (11.3.1937, Актаныш р-ны Чиялек а.), тележурналист, язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1989). Алабуга пед. ин-тын (1959), Ленинград Югары партия мәктәбен (1979) тәмамлый. 1959 дан Апас р-нында: «Бригадир» г-тасының хатлар бүлеге мөдире, 1961 дән ВЛКСМ район ком-тының 1 нче секретаре. 1963 тән (бүленеп) «Татарстан» Дәүләт телерадиотапшырулар компаниясендә, өлкән мөхәррир (1990 га кадәр), әдәби тапшырулар баш мөхәррире (1990–97), «Фикер» иҗади бүлеге мөдире (1997–98), «Илһамият» программасы мөхәррире һәм алып баручысы (1998 дән). Балалар өчен «Ләйсәннең бер җәе» (1971), «Офыкның аръягында» (1985), «Керәшен кызы» (1995), «Ак бишек» (1997) повестьлары; «Әткәй сәгате» (1994), «Ике як иңсәмдә» (2000) хикәяләр җыентыгы; И.Газиның «Онытылмас еллар» (1987), Н.Исәнбәтнең «Мырау батыр» (1989), М.Хәсәновның «Язгы аҗаган» (1991), Ә.Фәйзинең «Азат Мәргән» (1991), В.Имамовның «Өмет» (1992) әсәрләре буенча телеспектакльләр инсценировкалары, «Ялгыз учак» (1994), «Яңа фатир» (1995), «Сугышның ике көне» (1995) телеспектакльләре өчен сценарийлар; «Тормышым минем театр» (1996), «Тарих башы ерак гасырларда» (1998) кебек документаль фильмнар авторы. Респ-ка Журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. бүләге лауреаты (1991). ТАССРның Мактау грамотасы (1986) б-н бүләкләнә.

**СИРОТИ́НИН** Николай Николаевич (26.11.1896, Саратов ш. — 4.4.1977, Киев), патофизиолог, мед. фән. д-ры (1928), СССР МФА академигы (1957), Украина ССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1939), Украина ССРның атказ. фән эшлеклесе (1941). Саратов ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1924), Рязань-Урал тимер юлында бизгәк авыруы (малярия) станциясе мөдире булып эшли. 1925 елдан 2 нче Мәскәү мед. ин-тында. 1929–34 тә Казан мед. ин-тының патологик физиол. каф. мөдире, проф. (1930). 1934 тән Киев эксперименталь биол. һәм патология фәнни-тикшеренү ин-тында (хәзер А.А.Богомолец исем. Физиол. ин-ты) чагыштырма физиология лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре йогышлы һәм йогышсыз авырулар вакытында тере организмнарның реактивлыгын, гипоэнергия һәм аның йогышлы авыру барышындагы әһәмиятен өйрәнүгә; анафилаксиягә; аллергик реактивлыкның чагыштырма патологиясенә; организмнарның гипоксиягә җайлашу эволюциясенә; биек тау климатының кеше организмына тәэсирен тикшерүгә карый. Кавказ, Памир, Алтай тауларына оештырылган мед.-биол. экспедицияләр җитәкчесе (1928–76). СССР ФАнең А.А.Богомолец исем. бүләге лауреаты. К.Э.Циолковский исем. медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Основные положения профилактики и терапии гипоксических состояний // Физиология и патология дыхания, гипоксия и оксигенотерапия. Киев, 1958; Реактивность организма как основа проявления аллергии // Вестн. АМН СССР. 1964. № 10.

*Әд.:* К 80-летию со дня рождения Николая Николаевича Сиротинина // Патол. физиология и эксперим. терапия. 1977. № 1.

**СИРО́ТКИН** Александр Семёнович (20.8.1966, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (2003), проф. (2004). 1989 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, сәнәгый биотехнол. каф. мөдире (2004 тән). Хезмәтләре биотехнологиягә һәм экологиягә карый. С. агынты сулар чистартудагы биосорбция процессларының техник һәм экологик нигезләрен эшли. Актив күмерләрне биорегенерацияләү алымнарын тәкъдим итә. Флоккулалар, биокапламнар, микроблы гранулалар оешкан микроб күзәнәкләрен агрегирлау закончалыкларын тикшерә. Микроб агрегатларын нәтиҗәле куллануга, синтетик полимерлар биодеградациясе үзенчәлекләренә, күкерт кушылмаларын микроблы ачытуга, шулай ук агынты суларны фильтрлау барышында азот кушылмалары биотрансформациясенә караган мәсьәләләрне өйрәнә (фәнни эшкәртмәләре «Казан ясалма каучук заводы», «Түбәнкаманефтехим» АҖләрендә гамәлгә кертелә). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Современные технологические концепции аэробной биологической очистки сточных вод. К., 2002 (автордаш); Биообезвреживание концентрированных серусодержащих сточных вод химического производства // Хим. пром-сть сегодня. 2006. № 12 (автордаш); Агрегация микроорганизмов: флоккулы, биоплёнки, микробные гранулы. К., 2007 (автордаш).

**СИРО́ТКИН** Владимир Михайлович (21.8.1922, Сембер ш. — 2.6.1984, Казан), невропатолог, мед. фән. д-ры (1971), проф. (1976). Профессор Л.И.Омороков шәкерте. Воронеж мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1945), шунда ук нерв авырулары кафедрасында эшли. 1945 елдан 2 нче һәм 3 нче Украина фронтлары (Румыния, Венгрия, Чехословакия) һәм 3 нче Байкал арты фронты (Монголия, Кытай) гаскәрләре составында хәрәкәттәге армиядә. 1946 дан СССР Эчке эшләр министрлыгының сан. частьларында. 1954 тән Ульянов шәһәре поликлиникалары һәм хастаханәләрендә. 1957–74 тә Казан мед. ин-тының нерв авырулары кафедрасында, 1981 дән психиатрия каф. профессоры (мед. генетикасы курсын алып бара). 1974–81 дә Оренбург мед. ин-тының нерв авырулары каф. мөдире. Хезмәтләре мускулларның нерв регуляциясе патологиясенә, арминның мускуллар эшчәнлегенә тәэсирен өйрәнүгә карый. С. сирингомиелияне нибуфин б-н дәвалау ысулын тәкъдим итә, зоб авыруы вакытындагы невротик тайпылышлар клиникасын өйрәнә, дәвалау ысулларын эшли. Бөтенроссия невропатологлар һәм психиатрлар җәмгыятенең Оренбург бүлеге рәисе (1981). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Определение типа наследования при неполной генеалогической информации. К., 1973 (автордаш); Регионарные особенности микроциркуляции у больных сирингомиелией // Журн. невропатологии и психиатрии. 1974. № 10 (автордаш); Наследственность в развитии психических нарушений при церебральном атеросклерозе // Казан. мед. журн. 1983. № 5.

**СИРО́ТКИН** Вячеслав Владимирович (24.2.1967, Чабаксар ш.), географ, геогр. фән. д-ры (2003), проф. (2008). 1993 елда Петербург ун-тын, 1997 дә Чуаш ун-тын тәмамлый. 1997–2007 дә Чуаш ун-тында, табигатьтән файдалану һәм геоэкология каф. мөдире (2004 тән). 2007 дән Казан ун-тында, ландшафт экологиясе каф. мөдире (2008–2010), геогр. һәм картография (2011 дән) каф. мөдире. Хезмәтләре туфрак-грунтны гидрофизик тикшерүләргә карый. С. туфракны геоэкологик бәяләүнең интеграль үзлекләрен билгеләүнең аэродинамик ысулларын эшли. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы һәм 4 патенты бар.

Х е з м.: Гидрофизика почв. Чебоксары, 2002 (автордаш); Прикладная гидрофизика почв. Чебоксары, 2002 (автордаш); Геоэкологическая оценка почв. Чебоксары, 2007.

**СИРО́ТКИН** Лев Юрьевич (18.12.1952, Зеленодольск р-ны Карамалы Тау штп), педагог, пед. фән. д-ры (1993), проф. (1996), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1976 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Карамалы Тау мәктәбендә укыта. 1979–82 дә һәм 1992–99 да Казан пед. ин-тында, 1982–92 дә Алабуга пед. ин-тында. 1999 дан Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тында, педагогика һәм психология каф. мөдире (2000 нән). Хезмәтләре шәхесне формалаштыру проблемаларына карый.

Х е з м.: Школьник, его развитие и воспитание. Самара, 1991; Формирование личности: Проблема устойчивости. К., 1992; Нравственный выбор и его воспитание. К., 1995; Младший школьник, его развитие и воспитание. К., 1999 (автордаш).

**СИРО́ТКИН** Олег Семёнович (4.7.1949, Сахалин өлкәсенең Поронай р-ны Леонидово пос.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1993), проф. (1994). 1972 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1994–97 дә укыту-методика үзәге директоры. 2001 дән Казан энергетика ун-тында, проректор (2002–03), материаллар белеме һәм материаллар технологиясе кафедрасын оештыручы һәм аның мөдире (2001 дән). Хезмәтләре углеродсыз югары молекуляр кушылмаларга һәм алар нигезендәге материалларга карый. С. элемент-кислород бәйләнешле югары молекуляр кушылмалар химиясендә углеродсыз (нәорганик) полимер элементооксаннар фәнни юнәлешен үстерә. Нәорганик изо- һәм анизотроп полиэлементоксаннарны (полисиликатлар, полифосфат-



К.Х. Ситдыйков.

лар, полиборатлар һ.б.) газ фазасында синтезлау алымын эшли (бергәләп), газ һәм сыеклык фазалы технология буенча төрле кулланылыштагы пыяласыман капламнар, нәорганик пыялалар, бәйләгеч һәм үзле матдәләр, эластомерлар, керамик һәм композицион материаллар таба. А.М.Бутлеровның химик төзелеш теориясен дәвам итеп, үзенең химияне бердәм мөстәкыйль фундаменталь табигыять фәне буларак үстерү концепциясен тәкъдим итә (бердәм химия теориясе), моңа ул химик бәйләнешләрнең (ковалент-металл-ион) универсаль модельләрен, химик бәйләнешләр һәм кушылуларның «химик өчпочмак» рәвешендәге системасын булдыруны да кертә. Шуның нигезендә төп чылбырында сөрмә-азот бәйләнешләре булган нәорганик гетерочылбырлы макромолекулалар (полистибазаннар һәм полистибазеннар) булуын фаразлый (1987), синтезлый (1991) һәм аларның үзлекләрен тикшерә. Материаллар белеменең теоретик һәм практик аспектларын үстерүгә зур өлеш кертә. Фәнни эшләре ТР һәм РФ Электрон сәнәгате пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән. Уйлап табуга 40 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. Акробатика буенча СССРның спорт остасы (1973), ТАССР чемпионы (1972, 1974, 1978–80), РСФСР беренчелекләренең алтын һәм көмеш призлары иясе (1974, 1978–80). Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2008).

Х е з м.: Неорганические полимерные вещества и материалы (безуглеродные макромолекулы и полимеры). К., 2002; Начала единой химии (Унитарность как основа формирования индивидуальности, раскрытия уникальности и фундаментальности химической науки). К., 2003; Теоретические основы общего материаловедения. К., 2007.

*Әд.:* Выпускники — гордость технологического университета. КХТИ — КГТУ (1931–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000; Кто есть кто в российской химии: Справ. М., 2004; Казанский государственный энергетический университет (к 40-летию вуза). К., 2008. Т. 1.

**СИРТМӘКОЙРЫ́К КОШЛА́Р** (Motacilla), шул ук семьялыктагы кошлар ыругы. 11 төре билгеле, Евразиядә, Африкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә 6 төре бар. Сары сиртмәкойрык (M. flava), сары башлы сиртмәкойрык (M. citriola), ак сиртмәкойрык (M. alba) барлык районнарда да очрый; тау чәберчеге (M. cinerea), кара башлы сиртмәкойрык (M. feldegg), сары маңгайлы сиртмәкойрык (M. lutea) — республикада сирәк төрләр. Оя коручы һәм күчеп йөрүче төр. Кырларда, көтүлекләрдә, тугайлы болыннарда, торак пунктларда яши. Гәүдәсенең озынлыгы 16,5–18 *см*, авырлыгы — 14–20 *г*. Томшыгы юка, бизсыман, туры. Канатлары очлы. Койрыгы озын, аска-өскә даими тирбәнеп тора (исеме шуннан). Аяклары нәзек, озын. Сары сиртмәкойрыкның аскы ягы сары, аркасы яшел һәм башы соры төстә. Сары башлы ата сиртмәкойрыкның аркасы яшькелт-сары, канатлары һәм койрыгы коңгырт, койрыгының кырыйлары ак буйлы, башы һәм гәүдәсенең аскы ягы сары. Ана кошның төсе тоныграк, аркасы, башы һәм бүксәсе коңгырт төсмердә. Ак сиртмәкойрыкта ак һәм соры төсләр өстенлек итә; тау чәберчегенең өсте соры, аскы ягы һәм койрык өсте сары, койрыгы бик озын; кара башлы сиртмәкойрыкның башы кара төстә; сары маңгайлы сиртмәкойрыкның аркасы сары. С. ояларын җирдә, агач тамырлары, чыбык-чабык өемнәре астында,



Сары сиртмәкойрык.

кайвакыт агач куышларында коралар. Нигездә, апрель–майда, 4–7 чуар йомырка сала. Ел уңай килгәндә, ике тапкыр бала чыгара. Бөҗәкләр, суалчаннар, моллюсклар б-н тукланa. Корткыч бөҗәкләрне юк итеп, авыл һәм урман хуҗалыгына файда китерә.

**СИРФИДЛА́Р**, к. *Безелдәвек чебеннәр.*

**СИТДЫ́ЙКОВ** Айрат Габит улы (24.1.1973, Арча р-ны Олы Әтнә а.), археолог, ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2008), тарих фән. д-ры (2014). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1996). 1996–2001 елларда «Казан Кремле» тарих-архит-ра һәм сәнгать музей-саклаулыгы хезмәткәре. 2001–05 тә Казан архит-ра һәм шәһәр төзелеше баш идарәсе каршындагы Тарихи һәм мәдәни истәлекләрне саклау һәм файдалану буенча дәүләт контроле идарәсенең археол. күзәтчелек бүлеге башлыгы. 2004 тән ТР ФА Тарих ин-тының Археол. тикшеренүләр милли үзәге мөдире. Бер үк вакытта, 2008 дән, Казан ун-тының этнография һәм археол. каф. мөдире һәм «Казан кремле» музей-саклаулыгы директоры урынбасары. 2013 тән ТР ФАнең А.Х.Халиков исем. Археология ин-ты директоры. Хезмәтләре Казан ханлыгы чорындагы Казан тарихы һәм археологиясен, Түбән Идел буенда монголларга кадәрге чорда яшәгән халыкларны өйрәнүгә карый. Дәүләт бүләге Казанның меңьеллыгы концепциясен эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

Х е з м.: Древняя Казань глазами современников и историков. К., 1996; Средневековая Казань: Библиогр. указ. К., 2002 (автордаш); Казанский кремль: Ист.-археол. исслед. К., 2006.

**СИТДЫ́ЙКОВ** Айрат Сәлим улы (24.11.1964, Апас р-ны Сатламыш а.), физик, физика-матем. фән. д-ры (2011). Казан пед. ун-тын тәмамлый (1995). 1999 елдан Казан энергетика ун-тында, проф. (2011). Хезмәтләре атом төше физикасына, чикләнгән ферми системаларга һәм квант системаларының аксиоматик теориясенә карый. Югары спиннар һәм Е2-күчешләрнең китерелгән ихтималлыгы очрагында төзелгән полосаларның үз-үзен аномаль тотышы табигатен аңлата. Чикләнгән нуклон-ферми системаларның аксиоматик теориясен төзү өчен нигезләмә тәкъдим итә.

Х е з м.: Ротационные свойства ядер с $N \sim Z$ при наличии нейтрон-протонных корреляций // Ядерная физика. 2008. Т. 71 (автордаш); Semiclassical shell-structure in rotating fermi-systems // Phys. Rev. 2010. V. 81 (автордаш).

**СИТДЫ́ЙКОВ** Касыйм Хәсән улы (17.1.1913, Казан губ., Чистай өязе Мөслим а. — 13.3.1945), Сов. Союзы Герое (29.6.1945, үлгәннән соң), капитан. Командирлар составын камилләштерү курсларын тәмамлый (1938). 1935–37 һәм 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 458 нче укчы полкның батальон өлкән адъютанты (27 нче армиянең 78 нче укчы дивизиясе). Дала, Воронеж һәм 3 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Белгород-Харьков (1943) һәм Житомир-Бердичев (1943–44) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Тюкреш хуторы (Бичке шәһәреннән төньяк-көнбатыштарак, Венгрия) янында дошман контрһөҗүмен кире кайтарганда батырлык күрсәтә: 1945 нең 13 мартында сафтан чыккан рота командирын алыштыра. Шәхсән үзе яндыргыч сыекча б-н 2 танкны яндыра. Сугышта һәлак була. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медаль б-н бүләкләнә. Чистай шәһәрендәге бер урам С. исеме б-н атала. Туган авылында Геройга — бюст, Чистайда Геройлар аллеясында стела куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СИТДЫ́ЙКОВ** Нәҗип Халик улы (27.10.1900, Вятка губ., Малмыж өязе Мәчкәрә а. — 24.7.1961, Мәскәү, Казанда җирләнә), уролог-хирург, мед. фән. канд. (1949), ТАССРның атказ. табибе (1945). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1928), БАССРның Илеш р-ны Андреевка авылы участок хастаханәсе мөдире булып эшли. 1930 елдан Казан шәһәренең Сталин р-ны поликлиникалар берләшмәсе өлкән табибе. 1931 дән (бүленеп) Казан ГИДУВының 1 нче хирургия клиникасында, бер үк вакытта, 1938–41 дә, декан урынбасары, 1953–61 дә урология каф. мөдире. 1941 дә Көнбатыш фронтның 105 нче мед.-сан. батальонында госпиталь ротасы командиры, 498 нче кыр госпитале ординаторы. 1941–42 дә Көнбатыш һәм Калинин фронтларының 1319 нчы эвакогоспиталендә бүлек

башлыгы. 1942–43 тә 3076 нчы эвакогоспитальнең мед. часте башлыгы (Иваново ш.). Хезмәтләре урология өлкәсенә: сидек куыгы хирургиясенә, онкоурологиягә, сидек-җенес әгъзалары системасы травмалары очрагында тернәкләндерү хирургиясенә, бөер ташы авыруына диагноз кую һәм дәвалауга карый. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О методах диагностики и лечения камней мочевого пузыря // Казан. мед. журн. 1936. № 3; Случай рака мочевого пузыря в сочетании с гипернефромой правой почки // Казан. мед. журн. 1938. № 2; Клиническая оценка отдалённых результатов нефропексии // Урология. 1940. № 1 (автордаш); Отдалённые результаты хирургического лечения врождённого уродства типа Xyhopaqus parasiticus у ребёнка 50 дней // Акушерство и гинекология. 1957. № 6.

*Әд.:* Доцент Назип Халикович Ситдыков // Казан. мед. журн. 1961. № 5.

**СИТДЫ́ЙКОВ** Рәшит Исламетдин улы (26.4.1957, Зеленодольск ш.), вет. табибе, вет. фән. д-ры (2000), проф. (2001), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2007). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1983), шунда ук эшли, анатомия каф. мөдире (1999 дан, бер үк вакытта, 2000–06 да, вет. ф-ты деканы). Фәнни тикшеренүләре вет. иммуноморфологиясенә, риккетсиологиягә һәм а.х. терлеклекләре йогышлы авыруларына диагноз куюга карый. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Патоморфологические изменения в органах и тканях у овец, подвергнутых радиации и заражению возбудителем лихорадки КУ // Морфология. 1998. Т. 113, № 3; Результаты клинико-экспериментальных исследований сердечно-сосудистой системы при коксиеллёзе // Уч. зап. Казан. академии вет. медицины. 2006. Т. 183 (автордаш).


*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**СИТДЫ́ЙКОВ** Фәрит Габделхак улы (1.10.1938, Әгерҗе р-ны Иске Эсләк а.), физиолог, биол. фән. д-ры (1977), проф. (1978), ТССР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1990, 1999). 1961 елда Казан пед. ин-тын (хәзер Казан (Идел буе) федераль ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, кеше анатомиясе, физиологиясе һәм сәламәтлек саклау каф. мөдире (1974 тән), бер үк вакытта проректор (1976–2008). Хезмәтләре яшь үзенчәлекләренә бәйле рәвештә физик һәм акыл хезмәтендә йөрәк эшчәнлеген яраклаштыру һәм көйләүне өйрәнүгә карый. С. йөрәкнең ешлыгы һәм кыскару көченә симпатик һәм парасимпатик нервларның көйләгеч тәэсире урнашу вакытын билгели. Онтогенезда йөрәкне көйләүдә гумораль, гормональ һәм нерв факторларының үзара бәйләнеше турында яңа мәгълүматлар ала, төрлечә укыту режимына адаптация вакытында мәктәп яшендәге балаларда бөер өсте бизләре кабыгының, симпат-адреналин системасының ролен билгели. «Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек»не («Биологический русско-татарский толковый словарь», 1999) төзүчеләрнең берсе һәм авторы. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы һөнәри белем бирү хезмәткәре (1997).

Х е з м.: Сәламәтлек нигезләре. К., 2003 (автордаш); Лекции по возрастной физиологии сердца: Учеб. пособие. К., 2006 (автордаш); Гормональный статус и вегетативный тонус у детей 7–15-летнего возраста. К., 2008 (автордаш); Пуринорецепторы сердца в онтогенезе. К., 2011; Нервные и гормональные механизмы регуляции мышечной деятельности школьников. К., 2012.

**СИТДЫ́ЙКОВ** Эдуард Нәҗип улы (29.5.1931, Казан – 5.9.2016, шунда ук), уролог, мед. фән. д-ры (1971), ТР ФА академигы (1994), ТАССР, РСФСРның атказ. табибе (1970, 1988), ТАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1981, 2002). Н.Х.*Ситдыйков* улы. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1956), шунда ук, А.В.Вишневский исем. клиникадагы факультет хирургиясе кафедрасында (бүленеп: 1958–63 елларда — 2 нче Респ-ка клиник хастаханәсендә, 1960–70 тә урология каф. мөдире) эшли, 1970–96 да урология каф. мөдире, проф. (1972). Татарстанда урология хезмәтен оештыручыларның берсе; урологик авыруларга диагноз кую һәм дәвалауның заманча ысулларын эшли һәм гамәлгә кертә. 1970–80 елларда урология үсешендә Казан фәнни юнәлеше барлыкка килү һәм танылу, башлыча, аның эшчәнлеге б-н бәйле. ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш урологы (1970–90) буларак, шәһәр һәм район мед. учреждениеләре өчен урология белгечләре әзерләү, Чаллы, Әлмәт, Алабуга, Түбән Кама, Бөгелмә, Яшел Үзән шәһәрләрендә районара урология үзәкләре булдыру эшен оештыра. Хезмәтләре гомуми урология, онкоурология, энтероцитопластикага, сидек куыгында яман шеш булган авыруларны тернәкләндерүгә, мәни бизе авыруларын дәвалауга карый. Уйлап табуга 8 патенты бар. ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Основы реабилитации больных раком мочевого пузыря. К., 1994; Алгоритм ультразвукового мониторинга больных с новообразованиями мочевого пузыря до и после оперативного лечения. К., 1996 (автордаш); Лечение мочекаменной болезни методом дистанционной нефроуретеролитотрипсии. К., 2003 (автордаш); Уродинамика мочевых путей после цистэктомии с энтероцитопластикой. К., 2003 (автордаш).



Э.Н. Ситдыйков.

*Әд.:* Академик АНТ, профессор Эдуард Назипович Ситдыков // Казан. мед. журн. 2001. № 3.

**СИТДЫ́ЙКОВ** Эмиль Гариф улы (19.6.1923, Чистай ш. — май, 1989, Казан), график, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1983). Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый (1949). Харьков сәнгать ин-тында укый (1949–52). 1952 елдан — Татар сәнгать фондында. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1968). Графиканың күп кенә төрләрендә һәм жанрларында эшли (натурадан рәсем төшерү, плакат, гамәли графика), шулай да С. иҗатының төп юнәлешен тематик эстамп билгели. Ул 1950 еллардан төсләр һәм тоннар линогравюрасы техникаларында эшли. Казанда беренчеләрдән булып, тәгәрәтү алымын куллана, нәтиҗәдә тактадан алынган эзләр тональ көчешләргә бай булуы, төсләрнең бик нечкә көчеше б-н аерылып тора. Төсле линогравюра техникасында ландшафт һәм шәһәр пейзажлары сериясен эшли («Елга портында», «Бауман урамы», икесе дә — 1959; «Шәһәр бакчасында», «Балыкчы иртәсе», «Юлда», барысы да — 1963). Авыл хезмәтчәннәренә багышланган «Кызыл Байрак кешеләре» (1965–69), нефтьчеләргә багышланган «Баулы нефтьчеләре янында» (1974–80) линогравюралар сериялөрен иҗат итә. Образлы фикер йөртүдә шигъри гомумиләштерү, детальләр сайлауда кырыслык, ачык аңлаешлылык булган «Колхоз ветераннары» (1965), «Өйлә вакыты», «Бәхетле хатын» («Беренче бала») (икесе дә — 1967), «Гашыйклар (Гөлсем һәм Тәлгать)» (1968), «Бабай» (1969), «Баулыга юл»,





Э.Г. С и т д ы й к о в. 1. «Кызыл Байрак кешеләре». «Колхоз ветераннары» сериясеннән. Төсле линогравюра. 1965; 2. «Бәхетле хатын (Беренче бала)». Төсле линогравюра. 1967. Икесе дә — ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

«Бораулаучы портреты», «Бораулауда» (барысы да — 1974), «Баһадирлар» (1979) серияләреннән композицияләре аеруча популярлык казана. Ул агитплакат сәнгатенә зур өлеш кертә, аның хезмәтләренә сурәтләр һәм текстлар гармониясе («Безгә, Казанга рәхим итегез», 1970 еллар; «Уйларым көнемдә, төнемдә», 1977).

Респ-ка — ТАССР сынлы сәнгать күргәзмәләре (Мәскәүдә узган татар сәнгате һәм әдәбияты декадасы уңаеннан, 1957), «Татарстанның хәзерге заман графикасы» (Ульянов өлкәсенең шәһәрләре һәм авыллары, 1967), «Татарстан рәссамнары» (Мәскәү, 1968–69), «Совет Татарстаны рәссамнары» (Уфа, 1976; Баку, 1979; Мәскәү, 1980), зона — «Зур Идел» (1964, 1967, 1969, 1974), бөтенроссия — «Совет Россиясе» (Мәскәү, 1967, 1970, 1975, 1980), бөтенсоюз — «Тынычлык сагында» (Мәскәү, 1965) күргәзмәләрендә катнаша.

Әсәрләре ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТРның Милли музеенда, А.М.Горькийның Казандагы әдәби-мемориаль музеенда, Әлмәттәге Картиналар галереясында саклана.

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*М.С.Ильина.*

**СИТДЫ́ЙКОВА** Гүзәл Фәрит кызы (28.12.1968, Казан), физиолог, биол. фән. д-ры (2009), проф. (2011). Казан ун-тын тәмамлый (1991), шунда ук эшли. Хезмәтләре фенол кушылмалары, май к-талары, газсыман арадашчылар б-н нерв-мускул тапшыруы модуляциясе механизмын өйрәнүгә карый. С. арахидон к-тасының һәм аның метаболитларының хәрәкәт нервы очыннан медиатор секрециясен киметүен исбатлый. Азот оксиды, углерод монооксиды һәм күкертле водородның синапста медиатор алуның эндоген модуляторлары булып торуын күрсәтә.

Хезм.: Ионные каналы нервного окончания // Успехи физиол. наук. 2002. Т. 33, № 4 (автордаш); Газообразные посредники в нервной системе // Рос. физиол. журн. 2006. Т. 97, № 7 (автордаш).

**СИТДЫ́ЙКОВА** Марина Эдуард кызы (9.8.1954, Казан), уролог, мед. фән. д-ры (1994), проф. (1996), ТР, РФнең атказ. табибе (2004, 2015). Э.Н.*Ситдыйков* кызы. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), шунда ук эшли, 1994 тән урология каф. профессоры, 1996 дан — каф. мөдире. Германия һәм Франция клиникаларында стажировка уза. С. җитәкчелегендә респ-ка сәламәтлек саклау өлкәсендә урологик авыруларны дәвалауның иң яңа ысуллары (дулкын литотрепсиясе һ.б.) гамәлгә кертелә, аның тарафыннан сидек куыгын хирургик юл б-н дәвалау, цистэктомиядән соң өзлегүләрне кисәтүнең яңа ысуллары, артифициаль сидек куыгы ясау операциясе вакытында уретра-эчәклек анастомозы салу ысулы эшләнә; сидек куыгы рагының инфильтрацияләүче формалары һ.б. очракларда ул тәкъдим иткән диагностика алымнары иң катлаулы уроонкологик патологияләрне ачыкларга мөмкинлек бирә. Уйлап табуларга 6 авторлык таныклыгы бар. 11 рационализаторлык тәкъдиме авторы. Казан мед. ун-ты каршындагы урология буенча ординаторлар әзерләүче махсус бүлек җитәкчесе. Бөтенроссия урологлар җәмгыяте президиумы һәм Европа урологлар ассоциациясе (2003 тән), «Урология», «Вестник урологии» журналларының редколлегия әгъзасы. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Вторичный хронический пиелонефрит и цистэктомия. К., 1985 (автордаш); Основы реабилитации больных раком мочевого пузыря. К., 1994 (автордаш); Уродинамика мочевых путей после цистэктомии с энтероцистопластикой. К., 2003 (автордаш); Прогнозирование риска рецидива и метафилактика мочекаменной болезни. М., 2011 (автордаш).

**СИТДЫ́ЙКОВА** Һәдия Хәбибулла кызы (12.12.1913, Вятка губ., Алабуга өязе Мордва а. — 29.5.2000, Уфа ш.), нәкышьче, график, БАССРның халык (1983) рәссамы. 1937–68 елларда Уфада Башкорт сәнгать фондында эшли, шунда ук Р.М.Нурмөхәммәтовның сәнгать студиясен тәмамлый (1957). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1964).



Һ.Х.Ситдыйкова.

С. — иҗади үзенчәлекләргә ия рәссам. Натюрморт һәм интерьер жанрындагы милли йөзле картиналар авторы. С. әсәрләренең күпчелеге татар һәм башкорт халыклары көнкүрешенең, традицион культура әсәрләренең үзенчәлекле һәм бай күзәнәкле бизәкләренең матурлыгын (милли ашлар, өс киемнәре, халык музыка уен кораллары, сугыш кораллары), халык бәйрәмнәре темасын ачуга багышлана («Башкорт өендә. Иртәнге аш» (1963), «Башкорт балы» натюрмортлар сериясе (1964–76), «Кымыз» (1966), «Зәңгәр мендәрләр», «Ерак башкорт авылында» триптихы, «Төш» (барысы да — 1971), «Чәкчәк», «Бәйрәмгә» (икесе дә — 1972), «Авылда иртәнге аш» (1978), «Бала чагымнан» (1979), «Хәтер», «Әнием» (икесе дә — 1982), «Җиләкле натюрморт», «Аш өе» (икесе дә — 1987), «Казан сөлгесе», «Ак калфак» (икесе дә — 1989), «Зәңгәр шәл», «Батыр коралы» (икесе дә — 1991). С. натюрморт жанрында К.С.*Дәүләткилдиев*, А.Э.Тюлькин нигез салган традицияләрне дәвам итә, аларны дөньяны заманча кабул итү, декоративлык, формалар контрастлыгы һәм динамикасы б-н баета («Япон чәе белән натюрморт», 1975; «Ак кувшин белән натюрморт», 1978; «Шәфталулар», 1990; «Зәңгәр өслектә җиләк-җимеш», 1990; «Алсу пионнар», 1992). С., башлыча, майлы буяу һәм, график буларак, пастель б-н эшли, халык сәнгатенә якын торган ачык төстәге палитрадан (кызыл, зәңгәр, җирән, охра төсләрнең аралашып килүе) һәм шулай ук рухи, әхлакый сафлык билгесе булган ак төстән файдалана (еш кына фон сыйфатында).



Һ.Х.Ситдыйкова. «Курай». 1971. М.В.Нестеров исем. Башкорт дәүләт сәнгать музее. Уфа ш.

Респ-ка (1958 дән), зона — «Социалистик Урал» (1964–97), бөтенроссия — «Совет Россиясе» (Мәскәү, 1967, 1970, 1975, 1980, 1985), «Туган ил буйлап (Мәскәү, 1972), бөтенсоюз — «Хезмәткә дан» (Мәскәү, 1976), халыкара — «РСФСР рәссамнары нәкыше һәм графикасы» (Монголия, 1967; Болгария, Греция, Италия, Финляндия, Венгрия, Польша, Чехословакия, 1976–77), «Совет сәнгате» (Осака, Нагоя ш. Япония, 1972), бөтентатар — «Татарт» (С.-Петербург–Казан, 1991) күргәзмәләрендә катнаша.



Һ.Х.Ситдыйкова. «Батыр коралы». 1991. М.В.Нестеров исем. Башкорт дәүләт сәнгать музее. Уфа ш.

Шәхси күргәзмәләре Уфа (1960, 1983, 1988, 1993, 2003), Казан һәм Мәскәү (1985) шәһәрләрендә уздырыла.

Әсәрләре Дәүләт Третьяков галереясында (Мәскәү), М.В.Нестеров исем. Башкорт дәүләт сәнгать музеенда, ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, БДБ һәм башка чит илләрдәге тупланмаларда саклана. БРның С.Юлаев исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1993). 2008 дә Уфада С. яшәгән йортка мемориаль такта куела.

*Әд.:* Урманче Б. Без хәйран калдык // Азат хатын. 1983. № 6; Ртищева Л. Истоки своеобразия // Художники. 1982. № 9; Валеева А. Мир тепла и радости. Уфа, 1992; Адия Ситдикова. Выставка «Мелодии курая»: Живопись, графика. Уфа, 1993; Фенина Э.П. Художники Башкортостана. XX век. Уфа, 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**СИ́ТНИКОВ** Кирилл Прокофьевич (13.2.1899, Войско Донское өлкәсенең Михайловская станицасы — 19.1.1988, Казан), халык мәгарифе эшлеклесе, физика-матем. фән. канд. (1954). 1918 елдан Кызыл Армиядә, Гражданнар сугышында катнаша, 1920–22 дә НКВД органнарында. 1927 дә Мәскәү а.х. академиясен тәмамлый, шунда ук физика кафедрасында эшли, 1931 дән каф. мөдире. 1937–75 тә Казан ун-тында: ректор вазифаларын башкаручы, 1938–51 дә ректор, гомуми физика каф. мөдире (1951–63). С. җитәкчелегендә университет Бөек Ватан сугышы елларында фәнни һәм уку-укыту потенциалын саклап кала, сугыштан соңгы елларда уңышлы эшли. Өч Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ректоры Казанского университета 1804–2004 гг.: Очерки жизни и деятельности. К., 2004.

**СИ́ФИЛИС** (Сифилус — кеше исеме һәм лат. lues — йогышлы), кешенең барлык әгъза һәм системаларын зарарлаучы, рецидив бирү ихтималы булган йогышлы хроник авыру. «С.» сүзе беренче тапкыр Италия табибе Дж.Фракастороның көтүче Сифилусның авыруын тасвирлаган «Сифилис, яки галлар авыруы» («Сифилис, или галльская болезнь», 1530) поэмасында очрый. Европа һәм Азиядә неолит чоры каберлекләрен казыганда кеше сөякләрендә өченчел С. билгеләре (баш сөягендәге С.ка хас үзгәрешләр) табыла. Сугышлар, шәһәрләрнең үсүе, сәүдә элемтәләре киңәю, коллар б-н сату итү һ.б. С. таралуга сәбәп була.

С. авыруын төссез трепонема (Treponema pallidum) китереп чыгара. Инфекция чыганагы — авыру кеше, инфекция, башлыча, җенси мөнәсәбәт вакытында, үбешкәндә йога, ш.у. авыру кеше кулланган әйберләр аша көнкүрештә дә күчәргә мөмкин. Микроб кеше организмына лайлалы яры яки тиренең өске катламындагы бик кечкенә җәрәхәтләр аркылы үтеп керә. Трепонемаларның үтеп керү урынында беренчел сифилома (каты шанкр) барлыкка килә, лимфа төеннәре зурая, лимфа тамырлары ялкынсыну күзәтелә. Авыру йоктыру б-н авыруның беренче билгеләре күренү арасында 4–5 атна уза (инкубация чоры). Бу чорның озынлыгы антибиотиклар кабул итү, организмның иммунобиол. резистентлыгы төшү, начар туклану, берьюлы башка авырулар б-н авыру, өлкән яшьтә булу һәм башка сәбәпләр аркасында үзгәрергә мөмкин. С.ның беренчел чоры 6–8 атна дәвам итә, икенчел чор (авыру дәваланмаган очракта) 2 дән 4 елга кадәр сузыла һәм тимгелле таплар, папула һәм пустулалар (розеолалар) тибеп чыгу, чәч коелу б-н характерлана. Дәваламаганда, авыру яшерен стадиягә күчә, аның дәвамлылыгы кеше организмындагы иммунобиол. процессларга бәйле. С. б-н авыручы донор каны салынган очракта, реципиентта авыру икенчел С. билгеләре күзәтелүдән башлана; дәваланмаган очракта, 3–6 елдан (кайвакыт авыру йоктырганнан соң дистә еллар узгач) өченчел С. билгеләре күренә башлый (эчке әгъзалар, нерв һәм сөяк системасы зарарлана) һәм авыру үлә. Ачыкланмаган һәм дәваланмаган С. алдагы буынга күчә.

Россиядә С. таралу 15 йөз ахырына — 16 йөз башына туры килә. 18 йөзнең икенче яртысында А.Г.Бахерахтның венерик авырулар турындагы тикшеренүләре басылып чыга (1775). Венерология үсешенә ил медицинасына нигез салучы һәм әлеге фәнни юнәлешне барлыкка китерүче В.М.Тарновский, М.Я.Мудров, Н.И.Пирогов, И.Е.Дядьковский, Г.А.Захарьин, С.П.Боткин зур өлеш кертә. Аларның тикшеренүләре П.В.Никольский, И.В.Зеленев, Т.П.Павлов, П.С.Григорьев һ.б.ның хезмәтләрендә үстерелә.

Казан ун-тында 19 йөз ахырында С.ны һәм аның таралу сәбәпләрен өйрәнү б-н тире һәм венерик авырулар кафедрасына нигез салучы, «Венерик авырулар курсы» («Курс венерических болезней», 1892) дәреслеге авторы А.Г.*Ге* шөгыльләнә. 1870 елда В.О.Португалов «социаль авырулар» терминын тәкъдим итә. С. шундый авырулар төркеменә кертелә. 1903 тә А.И.Ефимовның «Рус авылында сифилис, авыруга хас билгеләр һәм халыкның санитар халәтенә аның тәэсире» («Сифилис в русской деревне, его характерные черты и влияние на санитарное положение населения») хезмәте басылып чыга. 1912 дә Казанда «Венерик авырулар белән көрәш лигасы» оештырыла, 1923 тә венерология диспансеры, С.ны кисәтүдә гаять мөһим роль уйнаган Санитария мәгарифе йорты ачыла. М.П.Батунинның «Сифилис вакытында рус препаратлары зильбер-новарсолан һәм новарсоланның терапевтик тәэсире» («О терапевтическом действии русских препаратов зильберноварсолана и новарсолана при сифилисе», 1925) хезмәтенең гамәли әһәмияте зур була. 1926 да Казанда Идел буе венерологларының 1 нче съезды уздырыла, 1927 дә Дерматологлар һәм венерологлар җәмгыяте оештырыла. 1930–38 дә Казан галимнәре В.М.*Аристовский* һәм Р.Р.*Гельтцер* тарафыннан С.ны китереп чыгаручы чиста культура аерып алына һәм аның үзлекләре өйрәнелә. 1956–64 тә С.М.Вяселева тәҗрибәләр юлы б-н С. вакытында пенициллин терапиясенең нәтиҗәлелеген нигезли. 1970 елларда Л.М.Устименко С.ны тудыручы микроорганизмның үзгәрүчәнлеген һәм авыру патогенезы механизмнарын өйрәнә (к. *Казан медицина фәнни мәктәбе*). С. проблемаларын өйрәнү б-н Казан мед. ун-тының тире-венерология кафедрасы хезмәткәрләре шөгыльләнә.

1996 да ТРда С. б-н авыручылар күрсәткече иң югары ноктага җитә (100 мең кешегә 263,2 очрак туры килә). Моңа эчкечелек, наркомания, фахишәлек, гомосексуализмның артуы, порнография таратуга күзәтчелек булмау, ш.у. халыкның миграциясе һәм туризм үсү сәбәп була. Шуннан соңгы елларда С. б-н авыру очракларының кимү тенденциясе күзәтелә (2008 дә 100 мең кешегә — 40,2, 2013 тә 24 очрак).

*Әд.:* М и л и ч М.В. Эволюция сифилиса. М., 1987; А д а с к е в и ч В.П. Инфекции, передаваемые половым путём. М., 2002; Б а н ч е н к о Г.В., Р а б и н о в и ч И.М. Сифилис и его проявление в полости рта. М., 2002; Р о м а н е н к о И.М., К у л а г а В.В., А ф о н и н С.Л. Лечение кожных и венерических болезней: В 2 т. М., 2006; А д а с к е в и ч В.П., К о з и н В.М. Кожные и венерические болезни: Учеб. рук. М., 2009.

*Р.З.Зәкиев.*

**СКАЛОЗУ́БОВ** Дмитрий Петрович (21.8.1839, Кострома ш. — 11.5.1892, Казан), невропатолог, медицина д-ры (1876). Мәскәү ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1868), Мәскәүдәге мед. оешмаларында эшли. 1870–81 елларда Мәскәү кара эшчеләр хастаханәсендә нерв авырулары бүлеге мөдире. 1876–85 тә Мәскәү ун-тында, 1884 тән нерв авырулары каф. мөдире. Бер үк вакытта, 1881 дән, Мәскәү полиция хастаханәсенең нерв авырулары һәм психиатрия бүлеген җитәкли. 1885 тән Казан ун-тында, невропатология каф. профессоры. 1887 дә кафедра нигезендә, мөстәкыйль учреждение буларак, ун-тның мед. ф-ты клиникасы һәм нерв авырулары каф. (Россиядә өченче) оештырыла. Хезмәтләре параличларны электр б-н дәвалауга карый.

Х е з м.: Руководство по электротерапии. М., 1881.

*Әд.:* И с м а г и л о в М.Ф. Памяти профессора Дмитрия Петровича Скалозубова // Неврол. вестн. 2000. № 1.

**СКАНДО́ВСКИЙ** Никанор Алексеевич (1798, Муром ш. — 20.8.1867, шунда ук), терапевт, медицина д-ры (1832), Казан ун-тының атказ. профессоры (1862). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый (1825). 1828 елда Дерпт шәһәрендә, 1833–35 тә Берлин һәм Вена терапия клиникаларында фәнни командировкада. 1835–63 тә Казан ун-тында: 1837 дән проф., клиника һәм психик авырулар һәм патологик семиотика каф. мөдире, 1861 дән госпиталь терапиясе клиникасы директоры. Казанда беренче Россия проф.-терапевты. Хезмәтләре физиологиягә һәм эчке авыруларга диагноз кую мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: О пользе знания народной медицины, особенно духовного звания. К., 1845; Краткая физиология человека, составленная для воспитанников Казанской семинарии, слушающих народную медицину. К., 1849; О тифозной горячке. К., 1859.

*Әд.:* Я н и ш е в с к и й Е.П. Из воспоминаний старого казанского студента. К., 1893; Б о г о я в л е н с к и й В.Ф., М а я н с к а я К.А., Т е р е г у л о в А.Г. Кафедра госпитальной терапии. К., 1976.

*В.Ф.Богоявленский.*

**СКАРЯ́ТИН** Николай Яковлевич (12.1.1823, Орёл губ., Малоархангельск өязе Троицкое а. — 28.4.1894, Смоленск губ., Сычёвка өязе Тесово а.), дәүләт эшлеклесе, тайный советник (1875). Дворяннар катлавыннан. Баш инженерлар уч-щесен тәмамлагач (С.-Петербург, 1840), хәрби һәм дәүләт хезмәтендә. Кырым сугышында (1855–56) һәм 1861 елгы Крәстияннәр реформасын үткәрүдә катнаша. 1859–65 тә Курск губернасы дворяннары башлыгы. 1866–80 дә Казан губернаторы. Изге Гурий борадәрлеген (1867) һәм Казан әҗнәби укытучылар семинариясен (1872) оештыруда булышлык күрсәтә, Н.И.Ильминскийның миссионерлык эшчәнлеген хуплый. С. губернатор булган дәвердә шәһәр театрлары өчен яңа биналар салына (1867,

1875), урамнар газ фонарьлары б-н яктыртыла башлый, суүткәргеч һәм атлы тимер юл төзелә (1875), сәнәгать һәм а.х. күргәзмәләре оештырыла (1879, 1880) һ.б. С. дәверендә ветеринария (1874) һәм укытучылар (1876) ин-тлары, Югары хатын-кызлар курслары (1876), ир балалар (1871; 1876 дан — Өченче ир балалар гимназиясе), кыз балалар (1976; 1880 нән — Ксения кыз балалар гимназиясе) прогимназияләре, игенчелек (1870) һәм һөнәр (1880) уч-щеләре, хезмәт (1867) һәм сәүдә (1867–70) биржалары ачыла; «Справочный листок г.Казани» (1867–68), «Казанский биржевой листок» (1868–92) һәм «Камско-Волжская газета» (1872–74) г-талары нәшер ителә. 1878–79 еллардагы *Татар крәстияннәре кузгалышын* аяусыз рәвештә бастыра. 1880 дәге сенатор ревизиясеннән соң отставкага җибәрелә, хөкемгә тартыла; 1883 тә аклана. Мемуарлар авторы. Казан икътисадчылары җәмгыяте президенты (1866–78). Чистай шәһәре мактаулы гражданы (1875).

*Әд.:* Б а р т е н е в П.И. Н.Я.Скарятин // Рус. архив. 1894. Кн. 2; М е д в е д е в П.М. Воспоминания. Л., 1929. *Е.Б.Долгов.*

**СКАЧКО́В** Всеволод Николаевич (1890 — 5.8.1918), Гражданнар сугышында катнашучы. 99 нчы запас полкта хезмәт итә, прапорщик (Пенза ш.). Февр. рев-циясеннән соң Солдат депутатларының Пенза советы полк ком-ты рәисе. 1917 елның октябреннән Казанда, Солдат депутатлары Советларының 2 нче хәрби округ съезды рәисе (Казан, 1917 нең ноябрь–декабре). Казан хәрби округы гаскәрләре б-н идарә итү буенча Комиссарлар Советы әгъзасы, демократияләштерү турында боерык һәм карарларны эшләүдә һәм тормышка ашыруда, хәрби частьләрне демобилизацияләүдә катнаша. Көньяк Уралда А.И.Дутов фетнәсен бастыру өчен отрядлар оештыра. 1918 дә Казан шәһәр хуҗалыгы Советы әгъзасы, Казан шәһәр Комиссарлар Советы рәисе, «Гражданская война» г-тасы мөхәррире. 1918 нең август башында Югары Ослан янында Чех-словак корпусы һәм КОМУЧ гаскәрләре б-н бәрелештә һәлак була.

*Әд.:* И о н е н к о С.И. Скачков Всеволод Николаевич // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

**СКВОРЦО́В** Александр Павлович (27.9.1946, Әлмәт р-ны Урсалы а.), тау инженеры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001), ТР-ның атказ. нефтьчесе (1993). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын (1975), РФ Хөкүмәте каршындагы Халык хуҗалыгы академиясен (Мәскәү, 2001) тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген 1963 елда Урсалы мәктәбендә укытучы булып башлый. 1967–2009 да (бүленеп) «Татнефть» АҖдә эшли: инженер, өлкән инженер, нефть чыгару буенча мастер, нефть промыселы башлыгы, «Әлмәтнефть» НГДУында башлык урынбасары, «Сөләйнефть» (1988 дән), «Җәлилнефть» НГДУларында (1997 дән) баш инженер, нефть промыселы җиһазларына хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау Әлмәт үзәк базасы башлыгы (2001 дән), АҖнең пластларның нефть бирүчәнлеген күтәрү һәм скважиналарны ремонтлау идарәсе башлыгы (2006 дан). «Әлмәтнефть» НГДУында партком секретаре урынбасары (1976–80), секретаре (1985–88 дә); Әлмәт скважиналарны капиталь ремонтлау һәм пластларның нефть бирүчәнлеге идарәсе парткомы секретаре (1980–82). Дәүләт бүләге эксплуатация колоннасын саклау һәм яңадан торгызу өчен техник чаралар һәм технологияләр комплексын эшләгәне һәм сәнәгатькә кертүе өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Обобщение и перспективы внедрения технологии повышения нефтеотдачи пластов в НГДУ «Джалильнефть» // Нефтепромысловое дело. 2000. № 11 (автордаш); Методика расчёта технологий нестационарного отбора нефти и закачки воды // шунда ук (автордаш).

**СКВОРЦО́В** Владимир Викторович (20.1.1931, Әстерхан ш.), математик, техник фән. д-ры (1972), проф. (1980). 1955 елда Мәскәү энергетика ин-тын тәмамлый. 1955 тән СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында, 1975 тән Казан технол. ун-тында, информатика һәм гамәли матем. каф. мөдире (1975–98), шул ук каф. профессоры (1998 дән). Хезмәтләре эксперт бәяләүләргә, расписаниеләр теориясенә, эвристик карар кабул итү процедураларына карый. С., беренчеләрдән булып, нефть чыганакларын эшкәртү теориясенә ихтималлыклар теориясе һәм матем. стат., шулай ук ЭВМда санлы хисаплау алымнарын кертә. Стат. модельләштерү һәм стат. сынаулар алымы ярдәмендә катлам беришсезлеге дәрәҗәсенең скважинаның дебитына һәм бирелүче басымга тәэсирен тикшерә. Тотрыклыланган фәзаи фильтрлану мәсьәләсен тикшерә, фильтрлау мәсьәләләрендә ихтималый Монте-Карло алымын куллану мөмкинлеген күрсәтә. Нефть катламы турындагы мәгълүмат тулы һәм төгәл булмаган яисә каршылыклы булган очракларда ихтималый эксперт бәяләве алымнарын тикшерә һәм үстерә. Математикага турыдан-туры бәйләнеше булмаган белгечлекләр буенча укучылар өчен укыту процессын мәгълүматлаштыру турындагы хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Математический эксперимент в теории разработки нефтяных месторождений. М., 1970; Методы экспертных оценок и их приложение в задачах теории фильтрации. К., 1976; Нескучные вычисления. М., 1999.

**СКВОРЦО́В** Иринарх Полихрониевич (7.8.1847, Самара губ., Бозаулык өязе Ромашкино а. — 1921, Киев), гигиена белгече, медицина д-ры (1847). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1871), Самара губернасының земство идарәсендә эшли. 1879 елдан Казан губернасының земство хастаханәсе өлкән табибе. 1882 дән — Варшава, 1885 тән — Харьков, 1906–21 дә Киев ун-тларында проф. һәм гигиена каф. мөдире. Хезмәтләре гигиенага, әйләнә-тирә мохитнең кеше сәламәтлегенә тәэсирен, гомуми сан. торышының ваба һәм тиф авырулары таралуга йогынтысын өйрәнүгә карый. Гигиология — сәламәтлек турындагы фән төшенчәсен тәкъдим итә.

Х е з м.: Нефтяной светильный газ в Казани. СПб., 1875; Беседы о холере: Наставление в видах предохранения от холеры и её устранения. Хар., 1893; Основы гигиологии и гигиены: Краткий курс для студентов и врачей. М., 1900.

*Әд.:* С в е р ч к о в А.Н. Идеи И.П.Скворцова в биологическом и медицинском значении электричества // Гигиена и санитария. 1967. № 7.

**СКВОРЦО́В** Эдуард Викторович (11.5.1940, Әстерхан ш.), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1982), проф. (1996), ТР-ның атказ. фән эшлеклесе (2002). 1963 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында, күзәнәкчел тирәлекләр бүлеге мөдире (1983 тән); ун-тның экол. системалар модельләштерү каф. мөдире (1995 тән). Хезмәтләре җир асты гидромеханикасына, деформацияләнә торган катламнарда фильтрлау теориясенә карый. С. башлангыч градиент басымлы фильтрлау теориясен үстерә, фильтрлау теориясендә экстремаль бәяләр ала, күзәнәкле туендырылган тирәлектә акустик дулкыннарга анализ үткәрә, пычрануларны грунтларда һәм катламнарда күчерү модельләрен тәкъдим итә.

Х е з м.: Плоские стационарные задачи фильтрации жидкости с начальным градиентом. К., 1978 (автордаш); Консолидация и акустические волны в насыщенной пористой среде. К., 1990 (автордаш); Фильтрация жидкости в деформируемых нефтяных пластах. К., 1999 (автордаш).

**СКЕТЧ** (ингл. sketch, — каралама), 19–20 йөзләрдә ике яки өч кеше катнашында куела торган кыска көлкеле пьеса. С.ка эчтәлекнең гадилеге, сюжетның хәрәкәтчәнлеге, хәлләрнең көлкелеге, парадоксальлеге, телнең үткенлеге, чишелешнең уңай булуы хас. Эстрадада киң тарала. Татар драматургиясендә бу жанрда эшләүчеләр арасында — Ә.Камал, Х.Вахит, С.Кальметов. *А.Г.Әхмәдуллин.*

**СКИ́МЕЛЬ-ОШЕ́** Виктор Николаевич (29.8.1925, Казан — 24.8.2002, шунда ук), математик һәм механик, физика-матем. фән. д-ры (1980), проф. (1984). 1952 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, теоретик механика каф. мөдире (1975–91). Хезмәтләре аналитик механикага, хәрәкәт тотрыклылыгы теориясенә, гироскопик системаларга карый. С. хәрәкәт катылыгы төшенчәсен кертә һәм аның теориясен үстерә, гироскопик системалар һәм приборлар динамикасы мәсьәләләрендә бу теориянең кулланылышын күрсәтә, Ляпунов функцияләре алымын дифференциаль тигезләмәләрне якынча чишү мәсьәләләренә карата куллана.

Х е з м.: Устойчивость гироскопов, гиростатов и гироскопических систем. М., 1965 (автордаш); О свойствах жёсткости движения // Прикладная математика и механика. 1978. Т. 42, вып. 2; Применение метода функций Ляпунова к некоторым задачам приемлемости приближённых решений дифференциальных уравнений // Прикладная математика и механика. 1992. Т. 56, вып. 6.

**СКИРДА́** Владимир Дмитриевич (23.12.1949, Краснодар краеның Выселки р-ны Березанская станицасы), физик, физика-матем. фән. д-ры (1994), проф. (2004), ТР-ның атказ. фән эшлеклесе (2007). 1974 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, молекуляр физика каф. мөдире (1994 тән). Хезмәтләре полимерларда төш

релаксациясенә һәм молекуляр хәрәкәтчәнлеккә карый. С. магнит кырының импульслы градиенты югары (100 Тл/м дан артык) булган ТМР приборлар эшли һәм градиентлы ТМР алымын куллану мәсьәләсен хәл итә. Сыгылма чылбырлы полимер эремәләрендә һәм эретмәләрендә макромолекулалар хәрәкәтенең универсаль характерда булуын күрсәтә. Полимер чылбыр элементларының трансляцион хәрәкәтчәнлеген беренче булып билгеле. Катлаулы полимер системаларда үздиффузия процессының төп закончалыкларын, ш.у. бикүзәнәкле (ике төрле, микро- һәм нанокүзәнәкләр) структураларда молекулаларның трансляцион хәрәкәтчәнлеге үзенчәлекләрен ачыклый. ТР Дәүләт бүләге иясе (2008).

Х е з м.: Самодиффузия в растворах и расплавах полимеров. К., 1987 (автордаш); Molecular exchange processes in partially filled porous glass as seen with NMR diffusometry // Phys. Rev. E. 1997. V.55, № 3 (автордаш); Generalized Concentration Dependence of Self-Diffusion Coefficients in Poly (allylcarbosilane) Dendrimer Solutions // Macromolecules. 2002. V.35 (автордаш).

**СКИФЛА́Р** (грек. skothai, фарсы. сака), Төньяк Кара диңгез буенда яшәгән борынгы кабиләләр (б.э.к. 7 йөз — б.э.ның 3 йөзе). С. һәм сакалар атамаларын греклар һәм фарсылар күпсанлы тугандаш кабиләләр берлекләренә карата кулланганнар, дип фаразлана. «С.» терминын элекке заманнарда Төньяк Кара диңгез, Дон һәм Түбән Идел буйлары терр-яләрен биләгән Иран телле күчмә халыкларга карата кулланалар. Б.э.к. 7 йөз ахырында Кара диңгез ярларының төньягындагы халыкны берләштергән кабилә берлегенең грекча атамасы антик чорда (б.э.к. 1 меңьеллыктан б.э.ның 5 йөзенә кадәр) Көнчыгыш Европа һәм Эчке Азия терр-ясендә яшәгән күпчелек халыклар өчен гомуми атамага әверелә. 3–4 йөзләргә караган чыганакларда төрле халыклар, ш.и. готлар, руслар, һуннар да скифлар дип аталып йөртелгән. С.ның килеп чыгышы мәсьәләсендә галимнәр уртак фикергә килә алмый.

Зур терр-ядә аларның хакимлеге урнашу тимер гасыр чәчәк аткан чорга карый. Җирле кабиләләрнең мәдәни-көнкүреш мөнәсәбәтләрендә үзгәрешләр барлыкка килә, һәм шуның нигезендә скифларның бу кабиләләрне берләштергән бертөрле мәдәнияте формалаша башлый. Скифия идарәчеләренең байлыклары һәм кодрәте, ш.у. кабиләләрнең миграцияләре Көнчыгыш Европаның, Үзәк Азиянең шактый зур терр-яләрендә һәм Евразиянең күпчелек халыклары, ш.и., ихтимал, борынгы төрки кабиләләр арасында да матди мәдәниятнең һәм мәет җирләү йолаларының гомуми формалары киң таралуга булышлык итә.

С.ның төп шөгыле күчмә терлекчелек була. Гаять зур көтүләр көтүлекләрне еш алыштыруны таләп итә, шуңа күрә С. өчен кыска вакытлы туктаулыклар һәм аз санлы даими торулыклар хас була. Киңлек юнәлешендә күчеп йөрүләр сезонлы меридиональ күчешләр б-н аралаша. Фаразланганча, Кырымда С.ның саны көзге-кышкы чорда арта. Язын һәм җәен күчмә халыклар Днепр һәм Дон буйларына күчеп китәләр. Алар терлекчелек продуктларын әзерли һәм эшкәртә беләләр: ит каклыйлар, сыр ясыйлар, ат дирбиясе, кием-салым, төрле кирәк-яраклар җитештерү өчен тире, йон һәм сояк кулланалар; терлекчелек (ирләр дә, хатын-кызлар да), аучылык (ирләр), һөнәрчелек б-н шөгыльләнәләр; эш һәм сугыш кораллары, бизәнү әйберләре ясыйлар; бронза, тимер һәм алтын таба һәм аларны эшкәртә беләләр (С. мәдәниятенә аеруча ит пешерү өчен бронзадан коеп эшләнгән казаннар хас). С. мәдәниятенең үзенчәлекләре скиф триадасында, ягъни сугыш коралларында, ат дирбиясе элементларында һәм С.га хас үзгә бер «җәнлек стиле»ндә эшләнгән сәнгать предметларында (реаль һәм фантастик хайваннарның хәрәкәттә сурәтләнеше, ерткыч җәнлекләрнең тояклы хайваннарны җәберләү күренешләре, төрле хайваннарны бер фантастик образда берләштереп сурәтләү) аеруча ачык чагылыш таба. Скиф сәнгатенең күп кенә әсәрләрендә мифологик күренешләр урын ала.

С. кыю сугышчылар һәм җәядән төз атучылар буларак танылалар; кара-каршы сугышканда хәнҗәр һәм ике ягы да үткен кылыч — акинак кулланалар. Гади сугышчыларның күн киемнәре һәм үгез тиресе тарттырылган агач калканнары, юлбашчыларның алтын һәм көмеш б-н бизәлгән металл киемнәре һәм кораллары була. С. Ассирия һәм Мидия кебек көчле дәүләтләрнең гаскәрләрен тар-мар итәләр, Мисыр чикләренә кадәр барып җитәләр. Кирәк вакытта сүтелгән һәм арбада күчереп йөртелгән, тирмәгә охшаш җиңел торакларда (агач колгалардан һәм хайван тиреләреннән корылган) яшиләр. Даими торулыкларында ярымземлянкалар һәм хуҗалык корылмалары була. Б.э.к. 5–6 йөзләр чигендә, кәсепчелек һәм сәүдә үсеш алган чорда, ныгытылган шәһәрләр барлыкка килә. Дөнья җәмәгатьчелегенә С.ның күп кенә каберлекләре мәгълүм. Мәрхүмнәрне чокырларда яки катакомбаларда курганнар (иң борынгылары — Адыгеяда Келермес һәм Украинада Мельгунов курганнары — б.э.к. 7–6 йөзләргә карыйлар) астына җирләгәннәр. С.ның патшаларын җирләү йоласы борынгы грек тарихчысы Геродот тарафыннан бәян ителә. Патша үлгәннән соң, аның гәүдәсен озак вакыт дәвамында «скиф юллары» буйлап йөртәләр, кабиләдәшләре хөкемдарларының үлеменә булдыра алган кадәр кайгырырга тиеш булалар. Патша б-н бергә кабергә ш.у. аның үтерелгән хатынын, хезмәтчеләрен, атларын да салалар һәм кабер өстенә курган өяләр. Ара-тирә С.ның каберләре өстенә яки изге урыннарга таш сыннар куела. Патша курганнарында алтын савытлар, алтыннан бизәкләп эшләнгән сәнгать әсәрләре, кыйммәтле сугыш кораллары табыла. Борынгы чорда ук курганнарның күпчелеге талана.

Скифия б.э.к. 4–3 йөзләрдә, бигрәк тә Кара диңгез буенда яшәгән күпчелек варвар кабиләләрен һәм грек колония шәһәрләрен үзенә буйсындырган Атей патша (б.э.к. 339 елда Македония патшасы Филипп II б-н сугышта һәлак була) идарә иткән чорда зур үсешкә ирешә. Б.э.к. 3 йөз ахырына сарматлар кысрыклавы нәтиҗәсендә С.ның биләмәләре шактый кими. Аларның башкаласы Кырымга күчерелә, анда Салгир елгасында (хәзерге Симферополь шәһәре чикләре эчендә) патша Скилур тарафыннан Скиф Неаполена нигез салына. Кырымнан тыш С. Днепр һәм Буг елгаларының түбән агымнары буйларындагы җирләрне дә элеккечә үк үз биләмәләрендә тоталар. Б.э.к. 2 йөздә С. Ольвияне һәм Херсонесның шактый гына җирләрен үзләренә буйсындыралар, тышкы икмәк сәүдәсенә хуҗа булырга омтылалар. С.ның Херсонесны яклап күтәрелгән Понтия патшасы Митридатка каршы сугышта җиңелүе нәтиҗәсендә вакытлыча көчен югалткан сәяси активлыгы 1 йөзнең икенче яртысында, патшалар Фарзой һәм Инисмей идарә иткән чорда, кабат көчәя (С. еш кына Боспор дәүләте б-н сугышалар). Б.э.ның 3 йөзендә үзәге Кырымда булган Скиф патшалыгы готлар тарафыннан юк ителә.

*Әд.:* Г р а к о в Б.Н. Скифы. М., 1971; А р т а м о н о в М.И. Киммерийцы и скифы. Л., 1974; Х а з а н о в А.М. Социальная история скифов: Основные проблемы развития древних кочевников евразийских степей. М., 1975; М у р з и н В.Ю. Происхождение скифов: Основные этапы формирования скифского этноса. Киев, 1990; П о г р е б о в а М.Н., Р а е в с к и й Д.С. Ранние скифы и Древний Восток: К истории становления скифской культуры. М., 1992.

*И.Л.Измайлов.*

**СКОБЕ́ЕВ** Валерий Николаевич (22.11.1938, Ульянов өлкәсенең Барыш р-ны Измайловка а.), нәкышьче, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1980), ТАССРның халык рәссамы (1986), РФнең атказ. рәссамы (2008). 1957 елда гаиләсе б-н Казанга күчеп килә. Казан сәнгать мәктәбен (1964), И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тының Е.Е.Моисеенко остаханәсен (1970) тәмамлый. Татар сәнгать фондында эшли (1970–83). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1974).

С. — тарихи, хәрби-патриотик жанрларда күп кенә әсәрләр иҗат итеп, респ-када сюжетлы-тематик картиналар үсешенә зур өлеш керткән әйдәп баручы рәссамнарның берсе: «Маёвка» (1971), «Юл» (1972), «М.Җәлил» (1974), «Төзелеш батальоны» (1975), «Игенченең өметләре» (1982), «Күл буенда» (1983), «Икмәк», «Гаилә» (икесе дә — 1985), «Сизену» (1990), «Торналар кайта» (1992), «Орфей йолдызлыгында» (2001). С.ка хас романтика, символик-аллегорик образларга тартылу аның КамАЗ төзүчеләргә һәм нефтьчеләр хезмәтенә багышланган картиналарында аеруча ачык чагыла: «Комсомол яшьләр» (1972), «Кама өстендә акчарлаклар» (1974), «Студентлар җыры» (1978), «КамАЗ металл коючылары», «КамАЗның калыпчы кызлары» (икесе дә — 1979). Хәрби темага иҗат иткән әсәрләре композицияләренең монументальлеге, образларның күтәренке рухлылыгы б-н аерылып торалар: «Сугыш юллары» (1970), «Зоя» (1971), «Җәлил һәйкәле янында» (1973), «Рус кыры» триптихы («Хушлашу», «1941 нең июне», «Эвакуация», 1980), «Солдат даны кайтавазы» (1980), «Узган сугыш кайтавазы» (1985). Аларга рухы б-н зур



В.Н.Скобеев.

күләмле «Революция тудырган» (1983) әсәре якын тора. Тематик картиналар б-н беррәттән, рәссам иҗатында нәкышь теленең фәлсәфи тирәнлеге, метафораларга байлыгы б-н сюжетлы-тематик картинага якын торган портрет жанры да зур әһәмияткә ия: «Артист Ф.Халитов портреты» (1972), «М.Җәлилнең лирик портреты» (1981), «Тукай. Гасыр башы» (1986), «Сергей Есенин, авылның соңгы шагыйре» (1995), «Ренат Харис. Шигърият сәхифәләре» (1998), «Владимир Высоцкий йолдызы» (1990–97;



В.Н.С к о б е е в. «Кама өстендә акчарлаклар». 1974. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

2003), «Николай Рубцов портреты» (2006), «Г.Тукай портреты» (2007), «А.И.Куприн. Тормыш сәхифәләре» (2008), «Фатих Кәрим. Фронттан соңгы хат» (2009).

«Алтынчәч» операсының тууы» (1986, 2005), «Н.Җиһанов музыкасында сугыш һәм тынычлык» (2008), С.Сәйдәшев, Ф.Яруллин, Н.Җиһанов, Р.Яхин истәлегенә багышланган «Татарстан музыкасының алтын гасыры», «Г.Тукай» (икесе дә — 2009) монументаль картиналарында рәссам үз алдына музыка иҗат итү процессын күрсәтүне максат итеп куя. С. ш.у. лирик пейзажлар («Яз», 1982), натюрмортлар, график әсәрләр (монотипия, карандаш) авторы да: «Тимерчеләр» (2008), нефтьчеләр һәм КамАЗ төзүчеләр портретлары (1970–80 еллар), ялангач натура: «Натурщица», «Модель» (икесе дә — 1968) серияләре.



В.Н.С к о б е е в. «Алтынчәч» операсының тууы. 2005.

Респ-ка (1970 тән), зона — «Зур Идел» (1974, 1980, 1991, 2003, 2004, 2008), бөтенроссия — «Совет Россиясе» (Мәскәү, 1975), бөтенсоюз — «Хезмәткә дан» (Мәскәү, 1976), «Бөек Октябрьгә 60 ел» (Мәскәү, 1977), «Ватан сагында» (Мәскәү, 1978), төбәкара — «Берләшү» (Түбән Новгород ш., 2007), Чехословакия, Румыния, ГДРда Совет сынлы сәнгатенең күчмә күргәзмәләре (1973), халыкара — Казанның 1000 еллыгына (Казан, Мәскәү, С.-Петербург, 2005), Г.Тукайның 120 еллыгына (Истанбул, 2006) багышланган күргәзмәләрдә катнаша. С.ның шәхси күргәзмәләре улы В.Скобеевныкы б-н бергә Казанда 1998 дә уздырыла.

Әсәрләре ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Россия Эчке Эшләр министрлыгының Үзәк музеенда (Мәскәү), Самара өлкә сәнгать музеенда, Чуаш сәнгать музеенда, Әлмәттәге Картиналар галереясында, Лениногорск шәһәрендәге нефть музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә саклана. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге лауреаты (1976).

*Әд.:* М и ң н у л л и н Р. Скобеевлар // Татарстан. 1999. № 3; Ф а й н б е р г А.Б. Молодые на зональных смотрах: В.Скобеев // Художник. 1975. № 12; М о г и л ь н и к о в а Г.А. Музей изобразительных искусств Татарской АССР. Л., 1979; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. М., 1984. *М.Е.Ильина.*

**СКО́ЛИЯЛӘР** (Scolioidea), шөпшәләр өссемьялыгы. ТРда төр составы җитәрлек өйрәнелмәгән. Ике семьялык: сколияләр (Scoliidae) һәм тифияләр (Tiphiidae) вәкилләре билгеләнгән. Tiphia femorata киң таралган; Нурлат, Чирмешән һәм Баулы р-ннарында ара-тирә дүрт нокталы С. (Scolia guadripunctata) очрый. Урман буйларында һәм куаклар арасында яши. Ана затлар күкәйләрен төрле пластинкамыеклы коңгызларның (бронзаклар, боланчык, мәрмәр коңгыз h.б.) личинкаларына сала. Шөпшә личинкалары коңгыз личинкалары б-н туена, аннары 5–40 *см* тирәнлектә туфракка күмеләләр һәм, кузы эрләп, шунда кышлыйлар. Олы затлар җәй уртасыннан сентябрьгә кадәр очалар, серкә һәм чәчәк нектары б-н туеналар. Аз санлы булганлыктан, үсемлекләрне серкәләндерүдә әһәмияте юк. ТРның Кызыл китабына кертелгән. *Е.А.Сапаев.*

**СКОМОРО́ХОВ** Владимир Иванович (15.6.1938, Мәскәү — 14.5.2014, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (1997). 1961 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый. Проектлаштыру КБларында («Теплоприбор», «Союз»), фәнни-тикшеренү ин-тларында (Мәскәү авиация технологиясе һәм җитештерүне оештыру ин-тының Казан ф-лы, Химия продуктлары, Бөтенсоюз хезмәтне саклау), югары уку йортларында (Казан химия-технол. ин-ты, Мәскәүдәге Бөтенсоюз тимер юл транспорты инженерларының читтән торып уку ин-ты, Казан техник ун-ты, Казан энергетика ун-ты) эшли. 2004 тән Кама инженерлык-икътисад академиясе профессоры (Чаллы ш.). Хезмәтләре физик химиягә, молекуляр физикага карый. С. тигез диссоциацияләшкән түбән молекуляр карбон к-талары парларының түгәрәк вертикаль торбада ламинар агышы вакытында локаль конвектив җылылык алмашын тикшерә. Берәмлеккә якын Льюис саннары булганда җылылык алмашу һәм тигезләнешле химик реакция процесслары уза торган җылылык алмашы һәм реакция аппаратларын исәпләү өчен гомумиләштерелгән бәйлелекне таба. Органик сыеклыкларда һәм аларның катнашмаларында молекулалар күчешен өйрәнә. Үзлелеге буенча молекулаларның ассоциация дәрәҗәсен исәпләү юлын тәкъдим итә. Кайнау темп-расында сыеклыклар үзлелегенең даимилеге законын, спиртлар, кислота, амин, эфир һәм кетоннарның гомологик рәтләрендә молекулаларның ассоциация дәрәҗәсе үзгәрү законын чыгара. Сыеклыкларда молекуляр хәрәкәт характеристикаларын билгеләү алымын эшли, эрегән матдә молекулаларының эреткеч молекулалары тирәлегендәге диффузиясе коэффициентын исәпләү тигезләмәсен чыгара. Органик сыеклыкларның үзлегеннән диффузиясе, үзлелеге һәм оптик үзлекләре арасындагы бәйлелекне ачыклый. Бинар сыек системалардагы үзара диффузиянең чик коэффициентлары буенча төрле органик сыеклыклар өчен молекула формаларының каршылык коэффициентлары кыйммәтләрен билгели. Техник яктан әһәмиятле матдәләрнең атм. басымы астында эрү темп-расыннан кайнау темп-расына кадәр арадагы күчерү үзлекләре турында белешмә материал төзи.

Х е з м.: Определение степени ассоциации жидкостей по их вязкости // Журн. физ. химии. 1992. Т. 66, № 11 (автордаш); Связь между самодиффузией, вязкостью и оптическими свойствами органических жидкостей // Журн. прикладной химии. 2004. Т. 77, вып. 1 (автордаш); Теплопроводность углекислого газа в критической области // Изв. вузов. Авиац. техника. 2005. № 2 (автордаш).

**СКОМОРО́ХОВ** Сергей Геннадьевич (25.4.1952, Саратов ш.), театр рәссамы, ТССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1990), ТРның халык рәссамы (2003), РФнең атказ. рәссамы (2012). Ростов-Дон шәһәрендәге М.Б.Греков исем. сәнгать мәктәбен (1972), М.Горький исем. МХАТ каршындагы мәктәп-студияне (1977) тәмамлый. 1975 елдан Комсомольск-Амур, Хабаровск, Чита, Тверь, Тула, Түбән Новгород, Чабаксар, Йошкар-Ола, Рамшайд (ФРГ) шәһәрләрендә эшли. 1984–94 тә Казан Зур драма театры баш рәссамы, 1995 тән — Татар акад. театрында. Театр эшлеклеләре берлеге (1981), Рәссамнар берлеге (1987) әгъзасы. Татарстанның әйдәп баручы сәхнә рәссамнарыннан берсе. Сыгылмалылык, төс һәм фактура бергә кушылган, хискә корылган декорацияләр авторы. С. килгәч, татар театрында режиссура һәм сценография арасында элемтә көчәя. Татар классикасы бу-

енча спектакль куелганда, ул милли мәдәният үзенчәлекләрен өйрәнә. С.ның төп фикере буенча катлаулы, формасы буенча кыска, ачык аңлаешлы декорацияләре функциональ универсальлеге, акцентларның төгәллеге б-н аерылып торалар. 150 дән артык спектакльнең, ш.и. Казан Зур драма театрында: В.Кудрявцевның «Иван һәм Мадонна» («Иван и Мадонна», 1985), Р.Болтның «Һәр заман кешесе» («Человек на все времена», 1986), А.Толстойның «Фёдор патша» («Царь Фёдор Иоаннович», 1988), А.Горинның «Мәрхүмне искә алу догасы» («Поминальная молитва», 1992), А.Чеховның «Ваня абзый» («Дядя Ваня», 1993); Татар акад. театрында: Ч.Айтматовның «Ахырзаман» (1989), Г.Исхакыйның «Зөләйха» (1994), Лопе де Веганың «Бию дәресләре бирүче» («Учитель танцев», 1995), Т.Миңнуллинның «Җанкисәккәем» (1995), Г.Камалның «Кайниш, көндәш һәм башкалар» (1996), Э. де Филиппоның «Гауґалы гаилә» («Суббота, воскресенье и понедельник», 1999), Т.Миңнуллинның «Илгизәр+Вера» (2000), Г.Хугаевның «Кара чикмән» («Чёрная бурка», 2003), З.Хәкимнең «Телсез күке» (2004), Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр» (2009), Г.Камалның «Банкрот» (2013), У.Шекспирның «Ричард III» (2014); Татар драма һәм комедия театрында: М.Фәйзинең «Галиябану» (1989), И.Гаетбайның «Алла сакласын!» (1991) пьесалары буенча куелган спектакльләрнең сәхнә бизәлешен әзерли.



С.Г. Скоморохов.

Зона — «Совет Ерак Көнчыгышы» (Владивосток ш., 1978, 1980), «Зур Идел» (Чабаксар ш., 1985; Казан, 1991), «Көлсу туфраклы җир рәссамнары» (Мәскәү, 1991); бөтенроссия — «Совет Россиясе» (Мәскәү, 1985), бөтенсоюз — «Театр, кино һәм телевидение рәссамнары» (Мәскәү, 1985, 1987) күргәзмәләрендә катнаша.

Шәхси күргәзмәләре Тверьда (1984), Бөгелмәдә (2000), Казанда (2002), Чабаксарда (2014) уздырыла.

Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге (1989), Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (2009) лауреаты.

*Әд.:* Сергей Скоморохов: Каталог выставки. К., 2002; С у л т а н о в а Р.Р. Современная сценография Татарстана: Каталог, К., 2002; ш у л у к. Главный художник Поволжья Сергей Скоморохов // Казань. 2004. № 1.

*Р.Р.Солтанова.*

**СКОРНЯКО́В** Христофор Николаевич (3.4.1862, Мәскәү губ. Коломна ш. — ноябрь, 1926, Симферополь ш.), педагог, нәкышьче. Офицер булып хезмәт итә, 1884 елда отставкага чыга, 1886 да САнә (С.-Петербург) укырга керә һәм аны 1890 да тәмамлый. Уку елларында 4 тапкыр көмеш медальләр б-н бүләкләнә. 1894 тә «Чүлле дулкыннар ярында» картинасы өчен 3 нче дәрәҗә үрнәк рәссам дәрәҗәсе бирелә. 1895 тә *Казан сынлы сәнгать мәктәбен* оештыручы һәм нигез салучыларның берсе, 1917 гә кадәр шунда нәкышь дәресләре алып бара; ш.у. Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында укыта. 1917 дән Симферопольдә яши, Кырым татар укытучылар семинариясендә рәсем укытучысы булып эшли, аннары Мәскәү сәнгать студиясендә, Кырымда хезмәт куя. Танылган укучыларыннан берсе — А.С.Жарков.



Х.Н.С к о р н я к о в. «Йөкче. Этюд». 1910 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

С. 19 йөзнең 2 нче яртысындагы рус реалистик нәкышь тарафдары була, акад. мәктәп традицияләрен дәвам итә. Иҗатында пейзажга (Кырым, Казан яны күренешләре), жанрлы картиналарга («Икона ясау остаханәсендә», 1890 еллар; «Палестина хаҗилары», 1914; «Йөкче. Этюд», «Йоклап ятучы балалар» — икесе дә 1910 нчы еллар) өстенлек бирә. Казан чорындагы жанрлы картиналарының күпчелеге гади халыкның хезмәте һәм дин темаларына (табыну, чиркәүләр, монастырьлар тормышы) багышлана. Рәссам, көндәлек көнкүреш сюжетлары иҗат итү б-н бергә, Россиянең 16–17 йөзләр тарихы темаларына да мөрәҗәгать итә, игътибарны күчмә күргәзмәләрдәгечә жанрлы картиналарның социаль юнәлешен фаш итүгә түгел, ә бәлки әйләнә-тирә мохитне тирәнтен, җентекләп өйрәнелгән дәрәҗәдә тапшыруга юнәлтә (интерьер, табигать, яктылык торышы һ.б.). 1900–10 еллар әсәрләрендә («Кырым тауларында», «Ай-Петри», «Иерусалимга бару юлында») табигый яктылык мохитенең образлы чишелешенә, панорамалы перспективаларга, нәфис төсләр нисбәтенә өстенлек бирә.





Х.Н.С к о р н я к о в. «Палестина хаҗилары». 1914. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Казанда узган картиналар күргәзмәсендә (1891), җирле һәм башка шәһәрләр рәссамнарының 1 нче күргәзмәсендә (1896–97) катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда (1907), Симферопольдә (1923) уздырыла.

Хезмәтләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Мәскәү, С.-Петербург, Симферопольдәге шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Каталог Первой выставки картин и этюдов местных и иногородних художников в помещении Казанской художественной школы. К., 1896; Русское искусство XVII — начала XX века. Живопись: Каталог. К., 2005. *И.Ф.Лобашёва.*





С.Г.С к о м о р о х о в. 1. Г.Хугаевның «Кара чикмән» спектакленә декорация эскизы. ДВП. Темпера. 2003; 2. К.Тинчуринның «Казан сөлгесе» спектакленә декорация эскизы. ДВП. Темпера. 2003.

**СКОРОБОГА́ТОВ** Андрей Валерьевич (1.12.1968, Кемерево өлкәсенең Киселёвск ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2005). Казан ун-тын (1993), Икътисад, идарә һәм хокук ин-тын (Казан, 2008) тәмамлый. 1993–99 елларда — Казан ун-тында, 2000–01 дә Казан а.х. академиясендә эшли. 2001 дән Икътисад, идарә һәм хокук ин-тында, дәүләт һәм хокук теориясе һәм тарихы каф. мөдире (2004–13). Хезмәтләре 18 йөз (император Павел I дәвере) Россия тарихына, историографиягә, дәүләт һәм хокук тарихы һәм теориясенә, хокукны аңлау һәм чагыштырма хокук мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Павел I в российской исторической литературе. К., 1999; Государство и общество в идеологии и политике императора Павла I. К., 2004; Цесаревич Павел Петрович: Политический дискурс и социальная политика. М., 2005.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**СКОРОХО́ДКИНА** Олеся Валерьевна (27.1.1964, Казан), аллерголог, мед. фән. д-ры (2004). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1987), шунда ук эндокринология, клиник иммунология һәм аллергология кафедрасында эшли. 1989 елдан Респ-ка клиник хастаханәсенең поликлиника бүлегендә. Хезмәтләре аллергик авыруларның билгеләрен өйрәнүгә,

авыруга диагноз кую һәм дәвалауга, яңа дару препаратлары уйлап табуга карый.

Х е з м.: Отечественное пиримидиновое производное ксимедон в базисной терапии бронхиальной астмы, осложнённой респираторной инфекцией // Мед. иммунология. 2001. Т. 3, № 2 (автордаш); Некоторые особенности течения атопических заболеваний у больных с ревматоидным артритом // Аллергология и иммунология в педиатрии. 2005. Т. 6, № 5 (автордаш).

**СКОРОХО́ДОВ** Михаил Евгеньевич (15.1.1926, Чистай ш. — 25.11.1994, Казан), язучы. М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1952). 1952 елдан Себердә эшли: Диксон утравында «Полярная звезда» г-тасы мөхәррире, Архангельск өлкәсе буенча ТАСС хәбәрчесе. 1968 дән Казанда яши. 1976–79 елларда Татарстан Язучылар берлегендә рус әдәбиятыннан консультант. «Океанга туры карап» («Лицом к океану», М., 1958), «Тимерказык йолдызы астында» («Под Полярной звездой», М., 1960), «Төньяк робинзоннары» («Северные робинзоны», Архангельск, 1965), «Ал җилкәннәр астында» («Под алыми парусами», 1970), «Кар тузанында» («В пыли снегов», 1986) хикәя һәм повестьлар җыентыкларында, «Өстен көчләр» («Превосходящие силы», Архангельск, 1961) романында диңгезче, аучы, балыкчы образларын, кырыс Себер табигате күренешләрен тудыра. 1967 дә Себердәге әкиятләр һәм риваятьләрдә сакланып калган Мангазея дигән шәһәргә Төньяк Боз океаны аша «Щелья» исемле карбас-көймәдә өч мең чакрымлык сәяхәткә чыга, анда алган тәэсирләре нигезендә «Щелья»да сәяхәт» («Путешествие на «Щелье», М., 1972) документаль повестен иҗат итә. «Кояшка каршы» («Встречь солнцу», 1980) шигырьләр җыентыгына Себер һәм Кама буе цикллары керә.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986. *И.И.Андреева.*

**СКРЕ́МЕНТОВ** Михаил Никифорович (1904, Казан губ., Казан өязе Каймар а. — 1.1.1949, Биектау р-ны Семиозёрка а.), Дан орденының тулы кавалеры (2.8.1944, 18.3.1945, 5.5.1946), старшина. Туган авылында колхоз рәисе булып эшли. 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 164 нче укчы полкта 82 *мм* лы миномёт расчёты командиры, миномётчы (1 нче һәм 3 нче удар армияләренең 33 нче укчы дивизиясе). Көнбатыш, 3 нче Балтыйк буе һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Демьян (1942, 1943), Псков-Остров (1943), Варшава-Познань (1945) һәм Берлин (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 16–24 июлендә Пушкинские Горы һәм Остров (Псков өлкәсе) торак пунктлары янындагы сугышларда батырлык күрсәтә: расчёт б-н дошманның 5 ут ноктасын һәм 1 взводка якын солдатын юк итә; 1945 нең 1–3 мартында Реч торак пункты (Польша) янындагы сугышта гаскәр б-н дошманның 3 ут ноктасын һәм 10 солдатын юк итә; 1945 нең 22 апреленнән 2 маена кадәр Берлин өчен сугышта, миномёт расчёты б-н җитәкчелек



М.Н.Скрементов.

итеп, дошманның 4 ут ноктасын, 8 фаустнигын һәм 15 тән артык автоматчысын юк итә. 1945 тә демобилизацияләнгәннән соң туган авылына кайта, Семиозёркада колхоз рәисе урынбасары, соңыннан хуҗалык эшләре мөдире булып эшли. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000. *М.З.Хәбибуллин.*

**СКРИ́ПКА**, сызгыч б-н уйный торган 4 кыллы музыка уен коралы. Татарлар 17 йөз ахыры — 18 йөз башында кулллана башлыйлар. Аңа кадәр 2 кыллы музыка уен коралы *кубыз* була, урта гасырларда аның 2 формасы (чиртеп уйный торган һәм сызгычлы) кулланылган, югары декасы тире б-н тышланган. Урта гасырлар азагында аның модификациясе — 3 кыллы гыжык барлыкка килә (соңыннан бу исем 4 кыллы скрипкага карата да кулланыла башлый); аның, кубыздан аермалы буларак, агач корпусы тулысынча ябык, тавышы көчле. Әлеге музыка уен коралларын акрынлап кысрыклаган борынгы татар С.сы аларның конструктив үзенчәлекләрен 20 йөзгә кадәр саклый: ул вертикаль тотыла; шпиле, башы һәм муены б-н бергә, тоташ агачтан киселә.

18 йөз уртасыннан 20 йөз башына кадәр татарларда С. төп музыка уен коралларының берсе була, халык һәм проф. башкаручылар тарафыннан ансамбль һәм соло музыка уен коралы буларак кулланыла. 18 йөздә концерт бирүче беренче скрипкачылар — Мөхәммәд бине Гали (Казы ака Ахун, 1696–1795), Ишмөхәммәд Заһит углы (1741–1840) барлыкка килә. 19 йөз уртасында һәм 20 йөз башында башкаручылар Г.Мәкәрҗә, Ончы Фәхри, М.Мостафин, Г.Г.*Ижбулдин*, Г.М.*Зайпин*, Х.*Әхмәдуллин* бик популяр була. Алар концертлар б-н чыгышлар ясыйлар, грампластинкаларга язылалар, скрипка миниатюралары һәм җырлар иҗат итәләр. 20 йөз башыннан проф. татар музыкасында С.ның европача варианты һәм көйләр башкаруның классик традицияләре киң таралыш ала. *Ш.Х.Монасыйпов.*


**СКУЛЬПТУ́РА** (лат. sculptura, sculpo — кисәм, уям), ую, пластика; сынлы сәнгать төре, формасы күләмле, өч үлчәнешле, каты яки пластик материаллардан: үзле балчык (чи һәм яндырылган), гипс, таш (мәрмәр, гранит, известьташ, шамот һ.б.), агач, сөяк, металл (бронза, бакыр, тимер) һ.б.дан ясалган сәнгать әсәре. С. технологиясе осталарның авторлык хезмәте (әвәләү, сырлау, каты материалларны эшкәртү) һәм таш кисү, калыпка салу, кою, чүкү һ.б. өстәмә эшләр б-н бәйләнгән. Төп төрләре — фәзада иркен урнаштырылган түгәрәк С. һәм дивар яссылыгындагы сын-рельеф (барельеф., горельеф). Станлы, монументаль, монументаль-декоратив, кече формалардагы (вак пластика) төрләргә бүленә.

С.ның Татарстан терр-ясендәге иң борынгы үрнәкләре — балчыктан ритуаль киемле хатын-кыз сыннары һәм таш стелалардагы корал (сугыш балталары, кинжаллар) рельефлы сурәтләре Ананьино археол. культурасына карый. Урта гасырлар болгар чорыннан вак пластиканың тиңдәшсез үрнәкләре: *Маклашеевка җайдакларының* бакыр сыннары, А.Ф.*Лихачёвның* археол. атласында теркәлгән дүрт йөзле баш кыяфәтендәге бронза балбал, Болгар шәһәрендә табылган, таштан уелган монгол йөзле ир-ат башы фрагменты сакланып калган. Алтын Урда чорыннан С.ның кече формалары үсеш ала — кабер ташларындагы яссы рельефлы уеп ясалган бизәкләр Казан ханлыгы чорында чәчәк ата (к. *Уеп ясалган кабер ташлары*). Фараз ителгәнчә, Әлмәт р-нының Елховой авылы тирәсендә табылган һәм сакланып калган бердәнбер тонык антропоморф сурәтле таш стела да Алтын Урда чорына карый (фаразлау буенча, күчмә кече сыннарның провинция үрнәкләре).

16 йөзнең 2 нче яртысы С. үрнәкләрен рус чиркәве архит-расы истәлекләрендә күрергә мөмкин. 18 йөз башында Казанда храмнарда иконостаслар һәм соңгы барокко пластик декорлары ясалган уеп бизәк төшерүчеләр артеле эшләгән (Зөя каласында Троица чиркәвенең патша ишеге, Казандагы Петропавел соборының фасадлары һәм интерьерларындагы декоратив күпертмә бизәк һәм ташка уеп төшерелгән рельеф бизәкләре). Ләкин С.ның, һөнәри сәнгать төре буларак, 20 йөз башына кадәр үсеш алган традицияләре булмый. Казанда С.-Петербургтан чакырылган скульпторлар проектлары буенча аз санлы һәйкәлләр һәм бюстлар, ш.и. Казанда беренче зур монумент-скульптура — Г.Р.Державин һәйкәле (С.И.Гальберг, 1847; җимерелә, 2003 елда сынчы М.М.*Гасыймов* тарафыннан торгызыла), Н.И.Лобачевский бюсты (М.Л.Диллон) куела. 1893–95 тә — агач эше, соңрак икона язу остаханәләрендә өйрәнчек булган, Казан сәнгать мәктәбенең якшәмбе классларына йөргән С.Д.*Эрьзяның* (Нефёдов) үсмерлек еллары Казан б-н бәйле.

1904 тә Казанга проф. акад. белемле сынчы оста П.В.*Дзюбанов* килгәннән һәм Казан сәнгать мәктәбендә скульптура бүлеге ачылганнан соң, җирле сынчы кадрлар күренә башлый. Ә 1908 дә Петербург САн тәмамлаган В.С.*Богатырёв* килгәннән соң, Казан сәнгать мәктәбенең эше күзгә күренеп алга китә. 1909–26 да ул С. бүлеге б-н җитәкчелек итә, хезмәт юлларын Казанда башлаган К.Зале, М.Скулме, Г.А.*Козлов*, В.В.*Кудряшов* һ.б. — аның шәкертләре. Богатырёв иҗатындагы әлеге еллар станлы С. өлкәсендә зур казанышлар б-н билгеләп үтелә: «Автопортрет» (1900), Н.А.Римский-Корсаков (1912), Л.Н.Толстой, Н.И.*Фешин* (икесе дә — 1913) портретлары, «Байракны алу», «Әсирләр» (икесе дә — 1914) һ.б. әсәрләре. Окт. рев-циясеннән соң Богатырёв Ленинның монументаль пропаганда планын тормышка ашыруда актив катнаша, вакытлы гипс һәйкәлләр тор-

















**Скульптура.** 1. Дүрт йөзле пот башы. Ташка уеп бизәк төшерү. 8–9 йөзләр. А.Ф. Лихачёвның археологик атласыннан. К., 1923; 2. «Маклашеевка җайдагы». Асылмалы йозак. Бронза. Идел буе Болгар дәүләте. 11–12 йөзләр; 3. Кабер ташы. Уеплау. 1309. Болгар дәүләт тарих-архит-ра музей-саклаулыгы; 4. Казандагы Петропавел соборы фасадындагы рельефлы декор. 1726; 5. Алабуга шәһәрендәге Троица чиркәвенең патша ишеге. Агач. Уеплау. Йөгертелгән алтын. 17 йөзнең 2 нче яртысы; 6. В.С. Богатырёв. «Н.И. Фешин портреты». Гипс. 1913. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 7. Н.И. Фешин. «Салаватулла». Агач. 1920–23. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 8. Б.И. Урманче. «Сагыш». Агач. Уеплау. 1966. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 9. С.С. Ахун. «Муса Җәлил». Бронза. 1957. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 10. М.М. Гасыймов. С. Сәйдәшев бюсты. Бронза. 1998; 11. В.М. Маликов. Казанда совет власте өчен көрәштә һәлак булганнарга һәйкәл. Аммонит. 1967; 12. А.М. Миңнуллина. «Су ташучы». Бронза. Казан. 2006; 13. И.М. Ханов. «Ватан-ана» һәйкәле. Бетон. Чаллы. 1975; 14. В.И. Рогожин. «Антон Петров». Бакыр. Чүкеп ясау. 1975; 15. Р.Г. Агафонов. «Батыр». Тонықландырылган гипс. Әлмәт картиналар галереясы. 1990; 16. Р.Х. Нигъмәтуллина. «Бишек җыры». Тонықландырылган гипс. 1957. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 17. Ә.С. Фәтхетдинов. «Наз» («Нәфислек»). Агач. Уеплау. Түбән Кама шәһәренең тарих музее. 1991; 18. Л.Г. Фәйзрахманова. «Суга бару». Бакыр. 2004.

гыза: Казандагы Ленин бакчасында В.И.Ленин бюсты (1920), 1 нче Май мәйданында «Эшче-металлист» (1921), элекке Юнысов мәйданында М.Вахитов һәйкәле (1922) (сакланмаганнар).

Станлы С.да Казан архит-ра-техник ин-тында скульптура остаханәсен Богатырёв б-н бергә җитәкләгән Г.А.Козлов эшли. Аның тарафыннан күп кенә композицияләр: «Ленин эш вакытында» (1924), «Ленин табуты янында», «Татар крәстияне», «Көтүче башкорт» (барысы да — 1925) һ.б. иҗат ителә. 1919 да Козлов янында Татарстанның әйдәп баручы сынчыларыннан берсе Б.И.Урманче шөгыльләнә башлый. 1920 еллар башында С.ның агачтан көнкүреш кече һәм портрет жанрларына В.В.Кудряшов (Идел буендагы ачлыктан интеккән крәстияннәр сыннары, «Ир-ат портреты», 1922 тирәсе) һәм Н.И.Фешин (портрет башлары, «Салаватулла», 1920 еллар башы) мөрәҗәгать итә.

1920 елларның 1 нче яртысында, Казаннан Богатырёв, Козлов, Кудряшов, Фешин китү сәбәпле, С. үсеше тукталып тора. 1937 дә Казанга Ленинград пролетар сынлы сәнгать ин-тын тәмамлаган С.С.*Ахун* кайта. Ул Татарстанда милли С.ның чишмә башында тора, проф. С. мәктәбен төзи (шәкертләре арасында — Н.И.*Гаделев*, В.М.*Маликов*, Р.Х.*Нигъмәтуллина*), 1949–51 дә Казан сәнгать уч-щесенең скульптура бүлеген җитәкли. Ахун, нигездә, гипс, мәрмәр, агач, фарфор кулланып, станлы С.ның портрет һәм тематик жанрларында эшли. Ул мәдәният эшлеклеләре Г.Тукай, Һ.Такташ, Г.Ибраһимов, М.Җәлил (шагыйрь исән чагында эшләнгән бердәнбер бюст), Н.Җиһанов, Р.Роллан образлары галереясын төзи; монументаль-декоратив һәм парк С.сы (Казан фонтаннары «Дөньяның хакиме — хезмәт булачак», «Балыкчы»; 1930 еллар) һәм вак пластика өлкәсендә эшли. Бөек Ватан сугышы елларында Ахун, Мәскәү скульпторлары Л.Е.Кербель һәм Л.М.Писаревский б-н бергә, Г.Тукайның бронза һәйкәле проектын әзерли (1958 дә Казанның хәзерге Тукай мәйданына урнаштырыла). 1930–50 елларда С.ның портрет жанрында К.С.Счастнев иҗат итә.

Бөек Ватан сугышы елларында Казанга эвакуацияләнгән скульптор В.В.*Ламмерт* иҗаты күренекле урын били. Ул антифашистик рухтагы С. әсәрләре иҗат итә; сугыштан соңгы елларда жанрлы (А.М.Горькийның Казандагы Әдәби-мемориаль музее экспозициясендәге «Минем университетларым» темасына күп фигуралы композицияләр), портрет (В.И.Качалов, К.С.Станиславский, В.И.Немирович-Данченко, актриса Л.П.Милова бюстлары) һәм монументаль-декоратив С. (Татар опера һәм балет театры фасадлары һәм интерьерларындагы орнаментлы рельефлар) өлкәсендә актив эшли. 1950 еллар башында Ахунның Казаннан китәргә мәҗбүр булуы сәбәпле, Казанда В.И.Ленинга, Г.Тукайга, М.Җәлилгә монументаль һәйкәлләр кую өчен Мәскәү сынчылары П.П.Яцыно (Ирек мәйданындагы В.И.Ленин һәйкәле, 1954), В.Е.Цигаль (Казан ун-ты янындагы студент В.И.Ульянов-Ленин һәйкәле, 1954; 1 нче Май мәйданындагы М.Җәлил һәйкәле, 1967) җәлеп ителә.

1950 еллар ахырыннан, Казанга 1920 елларда репрессияләнгән Б.И.Урманче әйләнеп кайткач, станлы С. өлкәсендә күтәрелеш сизелә (башлыча, портрет жанрында). Ул татар мәдәнияте эшлеклеләренең күтәренке рух б-н сугарылган портретларын иҗат итә (Г.Тукай, Г.Ибраһимов, М.Җәлил, Н.Исәнбәт, Ф.Әмирхан, Г.Кариев һ.б.); фәлсәфи эчтәлек б-н тулыландырылган, мәрмәрдә һәм агачта гәүдәләндерелгән халык образлары («Сагыш», «Сөембикә», «Шагыйрь Кол Гали», «Язгы моңнар») С.га милли үзенчәлек, тирән рух өсти. Татар халык мәдәнияте, фольклоры темасы вак пластикада майоликадан Г.А.Зяблицев («Шүрәле», 1957; «Гөлчәчәк», 1963), агачтан миниатюр фигуралар һәм композицияләр авторы Ф.С.Сотников («Сабантуй» сериясе, 1969–71) иҗатларында мөһим урынны биләп тора.

1960 елларның «кырыс стиле»нә хас үсеш юнәлешләре — скульптур формаларның гомумиләштерелгән яңача шәрехләмәсе, образлар героикасы В.М.Маликов иҗатында чагыла (тарихи портретлар, эшчеләр, нефтьчеләр портретлары, революционерлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар бюстлары). 1967 дә Казандагы М.Горький исем. Үзәк культура һәм ял паркында совет власте өчен көрәштә һәлак булганнарга һәйкәл аның мөһим әсәре булып тора. Р.Х.Нигъмәтуллина һәм В.И.Рогожин да иҗат юлларының башы 1960 елларга туры килгән скульпторлар плеядасына карый. Бу скульпторлар гаиләсенең эшчәнлекләрен соңрак кызлары М.В.Нигъмәтуллина һәм И.В.Рогожина дәвам итә. Тема киңлеге, жанр төрлелеге б-н генә түгел, бәлки һәркайсының әсәрләренә хас якты үзенчәлек б-н дә алар иҗаты Татарстан С.сында аерым урын алып тора. Беренче татар хатын-кыз скульпторы Р.Нигъмәтуллина көнкүреш жанрлы станлы пластикада милли үзенчәлекле юнәлеш булдыра. Аның бронзада, агачта, шамотта эшләнгән сюжетлы композицияләре («Бишек җыры», «Беренче сыйныфка баручылар», «Әллүки», «Ана»; «Г.Тукайга мәхәббәт илә» сериясе; «Татар театры» вак пластика сериясе, 1960–2007) С.ны яңа пластик чишелешләр б-н баета, лирика, йомшак юмор, милли төсмерләр өсти; күп кенә портрет образлары (С.Сәйдәшев, Ф.Шаляпин, Г.Тукай, Сөембикә ханбикә, С.Садыйкова) булачак монументаль С.ларның модельләре итеп уйланыла. В.И.Рогожин үзен тарихи портретлар һәм монументаль һәйкәлләр авторы буларак таныта (А.В.Вишневскийга, «Антон Петров» һ.б.). Монументаль-декоратив С. әсәрләре иҗат иткән әлеге скульпторлар гаиләсенең уртак иҗаты аеруча нәтиҗәле (ТРның С.Сәйдәшев исем. Зур концертлар залы, Яшел Үзәндәге Бөек Ватан сугышы Геройлары аллеясы интерьерларындагы бюстлар һәм барельефлар һ.б.).

Агачтан эшләнгән портретлар, татар халык әкиятләренә һәм заманча темаларга жанрлы композицияләр авторы («Математик Якушев портреты», «Пугачёв», «Батыр», «Яшьлек», «Ромашка», 1966–79), Казан сынлы сәнгать мәктәбе бинасында элмә мемориаль такталар (Н.Фешин һәм Б.Урманчега куелган), Җәлил посёлогында М.Җәлилгә, Юдино посёлогында (Казан) Я.А.Юдинга куелган һәйкәлләр һ.б. иҗат итүдә танылган оста Н.И.Гаделев тә «алтмышынчыларга» керә. И.А.Новосёлов, Ә.К.Бәширов, Н.П.Тузов, П.И.Макаров, Н.Я.Васильев портретлы һәм композицияле С. жанрында эшли. 1970 елларда Казан сынчылары коллективында А.Х.Әбдрәшитов исеме дә танылa (аның иҗат диапазоны — станлы портреттан алып, монументаль һәм мемориаль С. кадәр). Эшкә сәләт, төрле материаллар б-н эш итә белүе (агач, чүкелгән бакыр, бронза, алюминий) аңа көчле һәм эшлекле шәхесләрнең күпкырлы образларын тудырырга мөмкинлек бирә (С.Эрьзя, С.Сәйдәшев, Җ.Фәйзи, Н.Җиһанов, И.Зарипов, Ш.Мәрҗани, М.Вахитов). 1980–90 елларда Казан сынчылары төркеме яңа осталар — И.Н.Башмаков, Г.А.Богородская (металлдан монументаль-декоратив пластикада эшлиләр), Ф.Н.Фәсхетдинов (Һ.Такташ, 1982, С.Максуди бюстлары, 1999, «Борынгы акыл ияләре» эскизлар сериясе, 2001) б-н тулылана. 1970 еллар башында респ-када яңа сәнәгать (Чаллы, Түбән Кама) һәм нефтьчеләр (Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә, Азнакай, Баулы) шәһәрләренең бик тиз үсеп китүе нәтиҗәсендә С. шәһәр мәйданнары, парклары, әре җәмәгать корылмалары бизәлешендә зур үсеш ала; түгәрәк һәм декоратив рельефлы С. әсәрләре иҗат итүче (агачка, гипска, кирәч панногa һ.б. уеп бизәк төшерү) җирле проф. сынчылар барлыкка килә (Р.А.Агафонов, Л.П.Владыкин, А.К.Заһиров, Г.Н.Капитов, Р.З.Круглякова, Д.Н.Садретдинов, Ә.С.*Фәтхетдинов*). Көчле сынчылар коллективы Чаллы шәһәрендә оеша. С.ның архит-ра б-н кушылуы һәм гармонияле шәһәр мохите барлыкка китерү бурычы С.ның традицион булмаган формаларын тудыра. И.М.Хановның шәһәр фәзаларының ансамбльле чишелешләрен арх. Р.С.*Насыйров* б-н бергә тормышка ашырган әсәрләре (Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 30 еллыгына һәлак булган сугышчылар һәйкәле, Энтузиастлар бульварындагы композицияләр, шәһәр фонтаннары, керү билгеләре һ.б.); Р.М.Вахитовның «Татарстан» кунакханәсе интерьерындагы шамот рельефы, М.Г.Шәйдуллинның скульптур металл пластикасы (эретеп ябыштыру, чүкү, чүкеп бизәк төшерү), Р.З.Круглякова һәм Л.П.Владыкинның агачтан уелган панноларь — шуның үрнәкләре. Соңгы елларда тарихи портрет өлкәсендә (станлы композицияләр, бюстлар) халык тормышы, фольклор темаларына вак пластикада жанрлы композицияләр иҗат итәргә алынган Л.А.Зимина нәтиҗәле эшли («Ветераннар», «Көрәш», 1992–93). А.И.Дербилов иҗаты станлы агач портрет С.сының эмоциональ тәэсирен үстерүгә багышлана («Алтынчәч», «Япон кызы», «Яшь Тукай», С.Сәйдәшевкә элмә мемориаль такта, 1985–97); аның тарафыннан шәһәр сәнгать уч-щесендә скульптура остаханәсе оештырыла. А.Петровның портретлы рельефларына кече формалар һәм образларның

лирик яңгырашы хас («Цветаева Алабугада», «Тукай истәлегенә» сериаләре, 1985–94).

ТРның көньяк-көнчыгыш төбәкләренең әйдәп баручы скульпторларына 1970–90 елларда станлы һәм монументаль С. жанрларын актив үстерешкән Р.Г.Агафонов та керә. Ул — мәрмәр, бронза, бетон, тоныкландырылган гипс, бакыр, алюминий һәйкәлләр, бюстлар, стелалар, станлы композицияләр һәм портретлар, вак пластикалар авторы (Бөгелмә шәһәренең мәдәният паркындагы Геройлар бюсты, Лениногорск шәһәр хакимияте бинасы янындагы «Туган җир — угыллар таянычы», «Татарстан» скульптурасы, Әлмәттәге «Габдулла Тукай» стеласы, тарихи шәхесләр портретларының 12 плакеткадан торган сериясе һ.б.). Агафонов милли-романтик юнәлештәге С. үсешенә лаеклы өлеш кертә, аның әсәрләрендә («Батыр», «Яңа Болгар», «Мәүлә Колый» һ.б., 1990–97) халык героеның символик-аллегорик образы күзаллана.

Совет чоры С.сында күбрәк тышкы форма матурлыгына игътибар бирелә, табигый һәм кеше кулы тудырган материаллар кулланыла (үзле балчык, шамот, агач, металл), С.ны фәзаи мохиткә кайтару күзәтелә. Монументаль-декоратив, парк С.сы әсәрләре барлыкка килә, станлы портрет һәм вак пластика жанрлары үсеш ала (Казан рәссамнары А.Х., Г.А. һәм А.Х.Әбдрәшитовлар, Ә.К.Бәширов, И.Н.*Башмаков*, П.Ю.Бердников, Г.Н.Богородская, Т.Н.Кривошеева, А.М.*Миңнуллина* һ.б.). Монументаль С.ның, аеруча тарихи жанрның көчле үсеше 2005 тә Казанның һәм 2007 дә Алабуганың 1000 еллык юбилей даталары б-н бәйле (әмма эре объектлар чакырылган сынчылар А.В.Балашов, А.В.Головачёв, В.А.Демченко, Ю.А.Орехов тарафыннан эшләнә). Респ-ка сынчыларының иҗат коллективына яңа милли кадрлар кушыла (М.М.*Гасыймов* һәм К.Җ.*Җәмитов*); аерым сынчылар заказлы объектлар эшләү өчен башка төбәкләрдән Казанга килә (Р.Габбасов, А.Новиков, Ф.С.*Нуриәхмәтов*, Т.Ю.*Сөбханкулов*, Л.Г.Фәйзрахманова һ.б.).


2000 дә Н.Фешин исем. Казан сынлы сәнгать уч-щесендә яңадан скульптура бүлеге оештырыла; 2008 дә В.И.Суриков исем. Мәскәү акад. сынлы сәнгать ин-тының Казан ф-лында скульптура бүлеге ачыла. Ш.у.к. *Монументаль сәнгать, Монументаль-бизәлеш сәнгате*.

*Әд.:* Червонная С.М. Искусство Советской Татарии: Живопись, скульптура, графика. М., 1978; шул ук. Искусство Татарии: История изобразительного искусства и архитектуры с древнейших времён до 1917 года. М., 1987; Файнберг А.Б. Художники Татарии. Л., 1983; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Монументально-декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Султанова Р.Р. Искусство новых городов Татарстана. К., 2001; Кривошеева Т.Н. Скульптура Татарстана: истоки, становление, традиции. К., 2013.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**СЛА́ВИН** Лев Ефимович (3.4.1959, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (2001). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1982), Казан шәһәрендәге 15 нче хастаханәдә эшли. 1983 елдан Аксубай үзәк район хастаханәсе хирургы, хирургия бүлеге мөдире. 1986 дан — Казан ГИДУВының эндоскопия, 1988 дән гомуми эндоскопик хирургия кафедрасында. Хезмәтләре үт куыгы ташы авыруын хирургик юл б-н дәвалауга, операцияләр вакытындагы катлаулану очракларына карый.


Хезм.: Повреждения желчных протоков при лапароскопической холецистэктомии. М., 2003; Осложнения хирургии грыж живота. М., 2005.



А.Я.Славутский.

**СЛАВУ́ТСКИЙ** Александр Яковлевич (27.11.1947, Чиләбе ш.), актёр, режиссёр, педагог, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1986), РФ һәм ТРның халык артисты (1998, 2011). С.М.Цвиллинг исем. Чиләбе драма театры каршындагы студияне (1968), Б.В.Щукин исем. Мәскәү югары театр уч-щесенең режиссёрлык ф-тын (1974), Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-ты каршындагы югары театр курсларын (1980) тәмамлый. 1968–69 елларда Чиләбе яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) актёры, 1969–74 тә ВЛКСМның шәһәр ком-ты каршындагы Чиләбе яшьләр театры режиссёры, 1975–81 дә Чиләбе өлкә драма театры режиссёры; бу елларда куелган спектакльләр арасында «Чишеп булмаслык мәсьәлә» («Квадратура круга», В.П.Катаев; 1980), «Акылга сай Журден» («Полоумный Журден», М.А.Булгаков; 1981) бар. 1981–87 елларда Чита өлкә драма театрының баш режиссёры, анда ул «Скапен хәйләләре» («Плутни Скапена», Ж.Б.Мольер; 1981), «Өч апельсинга мәхәббәт» («Любовь к трём апельсинам», М.А.Светлов; 1981), «Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр» («На всякого мудреца довольно простоты», А.Н.Островский; 1982), «Әче!» («Горько!», М.М.Зощенко хикәяләре буенча; 1982), «Банкрот» (А.Н.Островский; 1984), «Күршедә яшибез без» («По соседству мы живём», С.Л.Лобозёров; 1986) спектакльләрен куя. 1987–93 тә Ростов-Дон акад. драма театрының сәнгать җитәкчесе, аның сәхнәсендә «Ревизор» (Н.В.Гоголь, 1989), «Америка фахишәсе, яки Әткече эти белән Россия буйлап сәяхәт» («Американская шлюха, или Путешествие по России с папой-алкоголиком», И.Квирикадзе киносценарие буенча; 1990), «Том Сойер маҗаралары» («Приключения Тома Сойера», М.Твен повесте буенча; 1991) спектакльләрен, «Түбәдәге скрипкачы» («Скрипач на крыше», Д.Бок, Д.Стайн; 1991) мюзиклын күрсәтә. 1994 тән Казан Зур драма театрының баш режиссёры, 2007 дән аның сәнгать җитәкчесе һәм директоры. «Бәхет — ул син!» («Счастье — это ты!», Б.Л.Васильев, А.П.Довженко хикәяләре буенча; 1995), «Хәтәр йомыркалар» («Роковые яйца», М.А.Булгаков повесте буенча мюзикл; 1997), «Тавык күзе» («Куриная слепота», Н.В.Коляда; 1998), «Пики дамасы» («Пиковая дама», А.С.Пушкин повесте буенча; 1999), «Өч тиенлек опера» («Трёхгрошовая опера», Б.Брехт, К.Вайль; 2000), «Верные йортындагы сер» («Тайна дома Верные», Р.Том; 2001), «Чия бакчасы» («Вишнёвый сад», А.П.Чехов; 2004), «Дама визиты» («Визит дамы», Ф.Дюрренматт; 2006), «Глумов» («На всякого мудреца довольно простоты», А.Н.Островский; 2007), «Абзыкай төше» («Дядюшкин сон», Ф.М.Достоевский повесте буенча; 2008), «Бөек комбинатор» («Великий комбинатор», И.Ильф романы буенча), «Унике урындык» («Двенадцать стульев», Е.Петров; 2009) спектакльләрен куя. С.ның иҗат алымына вакыйгаларны гәүдәләндергәндә масштаблылыкка, мизансценаны төзегәндә көчле тамашалылыкка омтылу, хореография, музыканы мул куллану хас. Рәссам А.М.Патраков б-н 30 елдан артык хезмәттәшлек иткән режиссёр спектакльләрнең үзенчәлекле куелышына зур игътибар бирә. С.ның күп кенә спектакльләре бөтенроссия һәм халыкара театр фестивальләрендә, ш.и. Вильнюс, Псков, Йошкар-Ола, Ярославль, Чиләбе, Магнитогорск, Самара шәһәрләрендә, ш.у. Каһирә (АРЕ, 1996), Марсель (Франция, 1997 дән 2001 гә кадәр ел саен һәм 2006 да), Охрид (Македония, 2005) кебек чит ил шәһәрләрендә дә тәкъдим ителә. С. Мәскәү, Орёл, Ла-Валлетта (Мальта), Битола (Македония) театрларында да спектакльләр куя. Бер үк вакытта театр каршындагы үзе тарафыннан 1995 тә оештырылган Россия акад. театр сәнгате ф-л-студиясендә пед. эшчәнлек алып бара, 2006 дан проф., РФнең Театр эшлеклеләре берлеге секретаре (2001 дән). ТРның Иҗтимагый палатасы әгъзасы (2006 дан). ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2000). РФ хөкүмәтенең Ф.Волков исем. бүләге лауреаты (2010). Дуслык ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Соколянский А. Уровень требовательности // Театральная жизнь. 1983. № 9; Казьмина Н. Александр Славутский: Время и место // Театр. 2006. № 3.



А.Я.Славутский куйган спектакльләрдән күренешләр:
1. «Чия бакчасы», А.П.Чехов; 2. «Хәтәр йомыркалар», М.А.Булгаков.

**СЛАВЯННАРНЫ́ ӨЙРӘНҮ́ ГЫЙЛЕМЕ́** (славистика), славян халыкларының тормышын, телен, әдәбиятын, фольклорын, тарихын, рухи һәм матди мәдәниятен өйрәнә торган фәнни дисциплиналар җыелмасы. Фән буларак 18–19 йөзләр чигендә Европада славян халыкларының «милли яңарыш» интеллектуаль проектларының соңарган мәгърифәтчелек һәм немец романтизмы идеяләренә нигезләнеп барлыкка килә. 1790 елларда чех галиме Й.Добровский славян халыкларының телләрен һәм мәдәниятләрен комплекслы өйрәнү бурычын куя. Европада С.ө.г. формалашуда И.Юнгман, Ф.Челаковский, Ф.Палацкий, В.Ганка, Я.Коллар, П.И.Шафарик хезмәтләре зур роль уйный. 19 йөзнең 1 нче яртысында славян һәм славян булмаган илләрдәге университетларда С.ө.г. кафедралары ачыла башлый. Чех тарихчысы, археологы һәм этнографы Л.Нидерленың «Славян халыкларының борынгы истәлекләре» («Славянские древности», 1–4 т., 1902–34) басмасы зур вакыйга буларак кабул ителә. 20 йөздә С.ө.г. белгечлеген алу дәвам итә, аерым славистика фәннәре барлыкка килә, Париж, Лейпциг, Берлин һ.б. шәһәрләрдә славяннарны өйрәнү үзәкләре оеша. Россиядә С.ө.г. барлыкка килү М.В.Ломоносов хезмәтләре б-н бәйле, галим славян телләренең кардәш телләр булуына, славяннарның дөнья мәдәниятендәге тарихи роленә игътибар бирә. Славян халыкларының борынгы истәлекләрен өйрәнү мәсьәләләре б-н 18–19 йөзләрдә В.Н.Татищев, И.Н.Болтин, Н.М.Карамзин һ.б. кызыксына. Фәнни славистик тикшеренүләрне оештыруда Г.Р.Державин һәм Н.А.Львов, Н.П.Румянцев һәм А.С.Шишков түгәрәкләре зур роль уйный. Славян телләрен чагыштырма-тарихи планда өйрәнә башлау акад. А.Х.Востоков (1781–1864) исеме б-н бәйле. Университетның 1835 тәге Уставы б-н Мәскәү, Петербург, Казан һәм Харьков ун-тларында С.ө.г. кафедралары ачыла, 1840 елларда алар б-н А.Х.Востоков шәкертләре О.М.Бодянский, И.И.Срезневский, П.И.Прейс, В.И.*Григорович* җитәкчелек итә. Славян телендә махсус вакытлы матбугат, фәнни оешмалар барлыкка килә.

С.ө.г.нең 1980–90 еллар чигендә башланган заманча этабы теоретик плюрализмны раслау, С.ө.г. дисциплиналары интеграциясенең яңа баскычында фәнни кызыксыну б-н характерлана.

Татарстанда С.ө.г.нең барлыкка килүе һәм үсеше Казан ун-ты һәм Казан руханилар академиясе галимнәренең хезмәтләрендә күзәтелә. Казанда С.ө.г.нә нигез салучы — В.И.Григорович, ул 1839 да Казан ун-тында славян шивәләре тарихы һәм әдәбиятлары кафедрасын җитәкли. Славян халыклары мәдәнияте тарихын комплекслы өйрәнү өчен, С.ө.г.н дөньяви масштабта гәүдәләндергәндә Григоровичның «Славян әдәбиятын аның мөһим дәверләре чигендә бәян итү тәҗрибәсе» («Опыт изложения литературы славян в её главнейших эпохах», 1842) хезмәтендә чагыштыру ысулы кулланыла. Аны үзләштергән вакытта славян тел белемендә славян телләрен өйрәнү өчен файдаланылган славян чиркәү теле үзенчәлекләре ачыклана, гомумән, глаголица һәм славян язуы барлыкка килү мәсьәләләре өйрәнелә. Григорович Казан руханилар академиясендә Россиядәге беренче текстологик мәктәпләрнең берсенә нигез сала, аның эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак, «Казан руханилар академиясе китапханәсендә саклаучы Соловки монастыре кульъязмалары тасвирламасы» («Описание рукописей Соловецкого монастыря, находящихся в библиотеке Казанской духовной академии», 1–3 кис., 1881–98) басылып чыга. Россиядә С.ө.г. тарихында Григоровичның славян җирләренә сәяхәте (1843–47) зур бер вакыйга була; аның тарафыннан славян телләре һәм диалектлары торышына караган бик күп мәгълүмат җыела, геогр. карталарга төгәллек кертелә, борынгы славян язуына караган кабатланмас истәлекләр (глаголицадагы Мария Евангелиесе һ.б.) табыла.

1860–1900 елларда С.ө.г. буенча тикшеренү эшләре Казанда М.П.*Петровский*, И.Н.*Смирнов*, Н.М.*Петровский*, И.А.Снегирёв, М.В.*Бречкевич*, А.М.*Селищев* һ.б. тарафыннан оештырыла. В.И.Григорович традицияләрен үстереп, алар славян диалектологиясенә караган мәсьәләләрне, славян әдәбиятлары тарихларын өйрәнәләр, славян язучыларының әсәрләрен тәрҗемә итәләр. Славян тел белеменә караган мәсьәләләрне өйрәнүгә И.А.*Бодуэн де Куртенэ* һәм ул нигез салган Казан лингвистика мәктәбе вәкилләре А.И.*Александров*, В.А.*Богородицкий* һ.б. зур өлеш кертә. Славян һәм борынгы һинд-европа телләренә чагыштырма (типологик) анализ өлкәсендәге ачышлар, телнең нигезен тәшкил иткән сөйләм эчтәлеген өйрәнү Бодуэн де Куртенэга фонемалар һәм фонетик чиратлашулар теориясен булдырырга һәм фонологиягә нигез салырга мөмкинлек тудыра. 1880 дә В.А.Богородицкий Казан ун-ты каршында Россиядә беренче эксперименталь фонетика лаб-ясен оештыра һәм С.ө.г.ндә яңа юнәлешкә — эксперименталь фонетикага нигез сала.

1917 дән соң Казанда С.ө.г. мәктәпләренең фәнни традицияләре гамәлдә өзелә. 1939 да, Казан ун-тының тарих-филол. ф-ты торгызылганнан соң, гомуми тарихи һәм филол. эзләнүләрне үз эченә алган тарихи тикшеренүләр чигендә С.ө.г. кабат тергезелә. Көньяк һәм көнбатыш славяннар тарихы, славян телләре һәм әдәбиятлары тарихы буенча курслар яңадан укытыла башлый. Казанда С.ө.г. историографиясе б-н А.В.Сергеев, А.С.*Шофман* шөгыльләнә, болгаристика проблемаларына — В.И.Адо, македониялеләрне өйрәнү гыйлеменә — А.С.Шофман, Көнбатыш Европадагы славян илләре тарихына һәм мәдәниятенә Я.Я.*Гришин*, Р.Р.*Йосыпов* һәм аларның шәкертләренең хезмәтләре багышлана. Славян әдәбияты һәм телләре тарихын өйрәнүгә — А.Н.*Вознесенский*, славян телләрен өйрәнүгә И.Э.*Еселевич*, Н.Е.Маркаръян, В.М.*Марков*, Г.А.*Николаев*, О.Ф.*Жолобов*, Н.Г.Николаева, Э.А.*Балалыкина*, Л.К.*Бәйрәмова*, Л.В.*Златоустова* һ.б. зур өлеш кертә.

*Әд.:* Ягич И.В. История славянской филологии. СПб., 1910; Шофман А.С. Изучение истории и культуры южных славян в Казанском университете // Вопр. славяноведения. К., 1962; Николаев Г.А. Из истории славяноведения в Казанском университете // 2 Славистические чтения памяти проф. П.А.Дмитриева и проф. Г.И.Сафронова: Материалы междунар. науч. конф. СПб., 2001; Макарова Н.И., Мягков Г.П. Отец и сын Петровские: два поколения Казанской школы славяноведения // Уч. зап. Казан. ун-та. 2006. Т. 148, кн. 4.

*Г.П.Мягков, Н.И.Недашковская.*

**СЛАВЯ́НОВА** Зинаида Михайловна (8.10.1882, Воронеж губ., Задонск өязе Скорняково а. — 18.1.1941, Мәскәү), актриса, режиссёр, педагог, җәмәгать һәм театр эшлеклесе, РСФСРның атказ. артисты (1933). Кыз балалар гимназиясен (Елец ш., 1897), пед. курслар (Мәскәү, 1900) тәмамлый. Сәхнә эшчәнлеген 1903 елда Тамбов шәһәре театрында башлап җибәрә, анда Грушенька («Бертуган Карамазовлар», Ф.М.Достоевский романы буенча), Регина («Өрәкләр», Г.Ибсен) рольләрен башкара. 1904–09 да Саратов, Пермь, Екатеринбург, Баку шәһәрләре театрларында актриса. Бер үк вакытта антрепренёрлык эшчәнлеге б-н дә шөгыльләнә. 1909–1919 да Самара шәһәрендәге драма театры актрисасы һәм режиссёры, 1918 дән баш режиссёры. 1919 да В.С.*Зотов* б-н бергә Казан Совет Зур театрына чакырып алына. Бер үк вакытта, 1919–21 дә, ТАССРның Мәгариф халык комис-тында театр бүлеге б-н җитәкчелек итә, 1919–24 тә Казан Зур драма театры каршында студия оештыра һәм аның б-н идарә итә. Бер үк вакытта, 1920–22 дә, Казан коммунистлар ун-ты һәм Казан югары халык мәгарифе ин-тында укыта, 1922–24 тә Татар театр техникумын оештыруда катнаша (З.Солтанов б-н берлектә), анда укыта, уку бүлеге мөдире була. Техникумдагы шәкертләре — Г.Булатова, Р.Ишморат, Г.Нигъмәтуллина, Х.Сәлимҗанов, Ф.Сәлләви һ.б. Казанда С. җитәкчелегендәге студияне СССРның булачак халык артистлары В.В.Белокуров, Е.Е.Жилина, Украина ССРның халык артистлары М.М.Белоусов, А.М.Таршин (Белоусов), ТАССРның атказ. артистлары Л.В.Володин, С.С.Осипов тәмамлый. Казанда С. сәхнәдә уйнавын дәвам итә. Ул башкарган рольләр арасында Василиса («Василиса Мелентьева», А.Н.Островский), Олимпиада («Савва», Л.Н.Андреев), Эмма Леопольдовна («Джентельмен», А.И.Сумбатов-Южин), Флория («Флория Тоска», В.Сарду) һ.б. бар. С., Россиядә хатын-кызлар арасында беренчеләрдән булып, проф. рәвештә режиссура б-н шөгыльләнә. Ул 1920 елларда Казанда 40 ка якын спектакль куя: «Маскарад» (М.Ю.Лермонтов), «Акыллылык бәласе» («Горе от ума», А.С.Грибоедов), «Бирнәсез кыз» («Бесприданница», А.Н.Островский), «Патша улы Алексей» («Царевич Алексей») һәм «Павел I» (Д.С.Мережковский), «Сергий атакай» («Отец Сергий», Л.Н.Толстой повесте буенча), «Канцлер һәм слесарь» (А.В.Луначарский), «Иң мөһиме» («Самое главное», Н.Н.Евреинов) һ.б. Үзе куйган спектакльләрдә С. сәхнә телен, режиссёр куллана торган сәнгатьчә чараларны яңартырга омтыла, мизансценаның пластик сәнгатилегенә игътибар бирә. Беренчеләр-

дән булып, В.В.Маяковскийның «Мистерия-буфф» пьесасына мөрәҗәгать итә һәм 1923 тә Казан Зур драма театры сәхнәсендә аның буенча спектакль куя. Репертуарны яңарту, аны эшче тамашачының революцион рухына якынайту бурычын күздә тотып, «Париж Коммунасы истәлегенә» («Памяти Парижской Коммуны») һәм «Кызыл ватанда» («На красной родине») пьесаларын яза һәм сәхнәләштерә. Яңа сәхнә телен һәм театраль формаларны теоретик нигезләү б-н шөгыльләнә, театраль культура тәрбияләү максатында әдәби һәм сәхнә геройларына «хөкем» чыгаруны гамәлгә кертә. 1920–21 дә Эшче һәм солдат депутатларының Казан советы составына керә. 1924 тә Казаннан китә. Аннан соңгы елларда Одесса, Әстерхан, Краснодар, Смоленск, Симферополь шәһәрләре театрларында эшли.

Х е з м.: Отдых. К., 1919; Рабоче-крестьянский театр. К., 1921; Памяти Парижской Коммуны. К., 1922; Четырнадцать спектаклей // Советский театр. 1936. № 9.

*Әд.:* С о б о л е в Ю. Женщина-режиссёр // Современный театр. 1929. № 10; Б л а г о в Ю.А. КЭМСТ и театральная жизнь Казани 1920-х гг. К., 2005; Театральная энциклопедия. М., 1965. Т. 4.

*Ю.А.Благов.*

**СЛАДКО́ВСКИЙ** Александр Витальевич (20.10.1965, Таганрог ш.), дирижёр, РФнең атказ. (2005) һәм халык (2016) артисты. Мәскәү (1988) һәм Петербург (2001) консерваторияләрен тәмамлый. 1997 елдан С.-Петербургта: 1997–2003 тә Дәүләт акад. капелласының симф. оркестр дирижёры, бер үк вакытта, 2001–03 тә, — С.-Петербург консерваториясендә Опера һәм балет театрының, 2004–06 да Капелланың баш дирижёры; 2006–10 да «Яңа Россия» («Новая Россия») дәүләт симф. оркестры дирижёры. 2010 нан ТРның Дәүләт симф. оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижёры. С. инициативасы б-н әйдәп баручы чит ил һәм ватандаш башкаручылар катнашуында Халыкара «Казан көзе» («Казанская осень») опера фестивале, С.Гобәйдуллина исем. «Конкордия» заманча музыка фестивале, халыкара «Рахлин сезоннары» («Рахлинские сезоны»), С.Рахманинов исем. «Ак сирень» («Белая сирень») фестивальләре һ.б. зур иҗат проектлары тормышка ашырыла. 2012 дә оркестр Халыкара «Worthersee Classics» (Австрия) муз. фестивалендә катнаша. 2012 дә С. ТРның Дәүләт симф. оркестры тарафыннан яздырылган «Татарстан Республикасы композиторлары музыкасы антологиясе» («Антология музыки композиторов Республики Татарстан»; С.Сәйдәшев, Н.Җиһанов, Ф.Яруллин, А.Монасыйпов, Ф.Әхмәтов, Р.Еникиев, А.Луппов, А.Миргородский, М.Шәмсетдинова, Р.Ахиярова, Ш.Тимербулатов, Р.Кәлимуллин һ.б.) дип аталган кабатланмас проектны гамәлгә ашыра. РФнең Федерация Советы рәисе каршындагы Дәүләт мәдәни сәясәте советы әгъзасы (2012 дән). С.Прокофьев исем. 3 нче Халыкара дирижёрлар конкурсы (1999), О.Янковскийның «2011–2012 елгы иҗади ачыш» («Творческое открытие 2011–2012») бүләге лауреаты. Татарстан Республикасының «Дуслык» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**СЛА́ЕВ** Валерий Абдуллович (31.8.1939, Саратов өлкәсенең Вольск ш.), метрология өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1990), проф. (1996), РФнең атказ. метрологы (1999). Ленинград электротехника ин-тын (1962), Ленинград инженерлык-икътисад ин-тын (1980), РФнең Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-каза китергән зыянны бетерү министрлыгының Гражданнар оборонасы академиясен (1996) тәмамлый. 1962 елдан СССР Оборона министрлыгының хәрби частенда (Красноярск краеның Енисейск ш.). 1965 тән СССР Суднолар төзү министрлыгының «Связь-морпроект» КБсында (Ленинград); 1966 дан Бөтенсоюз метрология фәнни-тикшеренү ин-тында (С.-Петербург): лаб., бүлек, сектор башлыгы, бүлекчә директоры, гыйльми секретарь. Хезмәтләре теоретик һәм гамәли метрологиягә карый. С. информацион үлчәү системаларында төгәл магнитлы язу аппаратларын метрологик яктан тәэмин итү нигезләрен эшли. Физик зурлык берәмлекләрен торгызу һәм аларның үлчәмнәрен башка төрле үлчәү чараларына тапшыру системалары теориясен төзи. Үлчәү алу төгәллегенең принципиаль чикләрен тикшерә. Элемтә каналы аша тапшырыла торган сигналларның тотрыклылыгын арттыру өчен, аларның сызыкча бозылулары һәм фильтрлау теориясен үстерә. Уйлап табуга 37 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Метрологическое обеспечение аппаратуры магнитной записи. СПб., 2004; Теория систем воспроизведения единиц и передачи их размеров. СПб., 2004 (автордаш); Предыскажения и фильтрация сигналов. СПб., 2005 (автордаш).

**СЛА́НЕЦЛАР**, вак бөртекле, катламлы (пластиналарга охшаш), җиңелчә метаморфик тау токымнары. Составы буенча С.ның 200 гә якын тибын билгелиләр. ТР терр-ясенең Идел һәм Зөя елгалары арасындагы юра утырмаларында гомуми ресурслары 30 млн. *т* дан артык булган *янучан сланецларның* 2 чыганагы (Бессоново һәм Кадыш) һәм 2 чагылмасы (Сөендек һәм Башчы) ачыклана. Респ-каның көнчыгышында Пермь, ташкүмер, девон һәм протерозой яшендәге токымнарда күмерле С. (к. *Казылма күмерләр*) билгеләнгән. Көньяк һәм көньяк-көнчыгыш районнарда, якынча 1900 *м* тирәнлектә карбон утырмаларында — карбонат-кремнийлы һәм аргиллитлы кара С., девонда коңгырт-соры, кремний-балчыксыл һәм битумлы С. табыла. ТРның көнчыгыш районнарында 1550 дән 3000 гә кадәр һәм тагын да тирәнрәк кристаллик нигездә кристаллик С. — күмерле, серицитлы, амфиболлы, биотитлы, хлоритлылар һ.б. ачыкланган, аларның яше 2 млрд. ел. С. җылылык энергетикасында (янучан һәм битумлы), вакланган таш, силикат (кремнийлы) кирпеч җитештерүдә; биналарны тышлау һәм түбәләрен ябу өчен һ.б. кулланыла.

*Әд.:* Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999; Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003.



З.М.Славянова.



А.В.Сладковский.

**СЛА́СТНИКОВ** Всеволод Степанович (15.10.1915, Омск өлкәсе, Тюкалинский өязе Лузино а. — 15.1.1972, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1939). 1939–40 елларда Павлоградтагы 55 нче з-дта (Украина ССР) эшли. 1940–55 тә 40 нчы Казан химия з-дында, директор (1952 дән). 1955–57 дә хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе. 1957–59 да КПССның Казан шәһәр ком-ты 1 нче секретаре. 1959–71 дә ТАССР МС рәисе урынбасары. 1971 дән ТАССР МС каршындагы Дәүләт план комиссиясе рәисе. 1955 тән ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**СЛАСТУ́НИН** Анатолий Алексеевич (28.2.1937, Буа р-ны Сосновка а. — 17.4.2008, Казан), музей эшлеклесе, ТАССРның атказ. мәдәният эшлеклесе (1987). Казан ун-тын тәмамлый (1968). 1963 елдан ТАССР Мәдәният министрлыгында музей эшләре буенча инспектор. 1989–2006 да ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее директоры. С. җитәкчелек иткән чорда экспонатларны саклау шартлары яхшыртыла, экспозиция мәйданы киңәйтелә; 2 нче музей корпусы төзелә, анда депозитарий һәм 3 күргәзмәләр залы урнаштырыла (1996), музей ф-лы буларак «Хәзинә» Милли сәнгать галереясы ачыла (2005).

**СЛЕПА́К** Захар Моисеевич (10.2.1932, Казан), геолог-геофизик, геол.-минерал. фән. д-ры (1986), проф. (1987), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1955), ТАССРның җитештерү оешмаларында. 1965 елдан Казан ун-тында. Хезмәтләре нефтьле структуралар һәм археол. истәлекләрне эзләүнең гравиметрик ысулларына карый. С. борынгы корылмаларның калдыкларын фаразлау, нефтьле структураларны эзләү, җир кабыгының тирәнлек төзелешен өйрәнү алымнарын эшли. Татарстан терр-ясендә җир кабыгы токымнарының тыгызлыгы үзгәрешләренең закончалыклы үзенчәлекләрен билгели. Инженерлык геологиясе һәм геофизикасында яңа фәнни-архит-ра истәлекләрен һәм борынгы корылмаларны саклау максатыннан урбанлашкан терр-ярләрдә геофизик мониторинг юнәлешен нигезли. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Геофизический мониторинг для сохранения памятников архитектуры. К., 1999; Гравиразведка в нефтяной геологии. К., 2005; Геофизика для города. М., 2007.

**СЛЕПКО́В** Василий Николаевич (февраль 1902, Рязань ш. — 1.8.1937, Мәскәү), генетик, фән методологы. Ленинград ун-тын (1927) һәм Кызыл профессура ин-тын (Мәскәү, 1929) тәмамлый. 1929 елдан Казанда: Татар коммунистлар ун-тында укыта, 1931 дән Казан ун-тының табигыять белеме методологиясе каф. профессоры, дрозофилаларда индуцирланган мутагенез һәм цитогенетика мәсьәләләрен өйрәнүче лаб-яне оештыра. 1932 дә Казан ун-ты каршында Биол. фәнни-тикшеренү ин-ты директоры булып билгеләнә; бер үк вакытта мед., а.х. һәм пед. ин-тларында лекцияләр укый. Генетика буенча семинарлар үткәрә, аларда исә Казан ун-ты аспирантлары һәм хезмәткәрләре (ш.и. булачак акад. биохимик А.А.*Баев*) катнаша. 1933 тә кулга алына, 3 елга Уфа шәһәренә җибәрелә, биредә укытучылык эшчәнлеген алып бара һәм дрозофилаларда тәҗрибәләр үткәрүне дәвам итә. 1937 елда контрреволюцион эшчәнлектә гаепләнә һәм атып үтерелә; үлгәннән соң аклана (1957).

Х е з м.: Наследственность и отбор человека // Под знаменем марксизма. 1925. № 4; Биология человека // Под знаменем марксизма. 1925. № 10/11; Евгеника: улучшение человеческой природы. М.–Л., 1927; Получение мутаций рентгеновскими лучами у Drosophila melanogaster // Журн. эксперим. биологии. 1928. Вып. 34 (автордаш).

*Әд.:* Д у б и н и н Н.П. Вечное движение: Воспоминания. М., 1989; Возвращённые имена: Док. очерки. К., 1992; Е р м о л а е в А.И. История генетических исследований в Казанском университете. К., 2004.

*Б.И.Барабанщиков.*

**СЛИ́ВА** (Prunus), розачалар семьялыгыннан җимеш бирә торган төшле үсемлекләр ыругы. Йорт сливасының туган җире булып Кавказ, Кече Азия, Төньяк Иран санала. Культурадагы сортларының башлангычы — алыча һәм күгән. Агач яисә 5–6 *м* биеклектәге куак формасында үсә. Яктылык һәм дым яратучан үсемлек. Үрентеләре төкле яисә төксез. Яфраклары формасы һәм төсе буенча төрлеләнә. Чәчәкләре чәчәк төркемендә берәрләп яисә 2–5 чәчәк булып урнашкан, уртача һәм эре, ак төстә кайвакыт яшькелт төсмерле була. Җимеше итчел, бер орлыклы, төрле формадагы, төстәге, зурлыктагы каты төшле җимеш, тәме һәм өлгерү вакыты төрлечә (җимешенең зурлыгына һәм төсенә карап, С.ның барлык сортлары да помологик төркемнәргә аерыла: «Венгерка» — куе төстә, ренклодлар — яшькелт, йомыркасыманнар — сары төстә, мирабелалар — җимешенең формасы һәм тәме буенча алычага охшаган). С. җимешләре яңа өлгергән һәм эшкәртелгән (компот, кайнатма, сок, төнәтмә һ.б.) килеш кулланыла. 5–6 нчы елда җимеш бирә башлый, 15–60 ел яши (ялганган үсемлекләр — 25–30 ел, үз тамырлылары 40–60 елга кадәр яши). Җимеш бирүче агачның уңышы 20–30 *кг* га кадәр (ел саен җимеш бирми). Җимешләре августта – сентябрь башында өлгерә. Яңа өлгергән килеш куллану өчен составында шикәр күп булган эре җимешле венгеркалар һәм ренклодлар кыйммәтле санала. С. составында шикәр (10–12%), органик кислоталар — алма, лимон һ.б. (0,4% тан 1,4% ка кадәр), азотлы матдәләр, $B_1$, $B_2$, C, K, PP витаминнары, каротин бар.

Татарстан терр-ясендә 17 йөздән үстерелә. Иң киң таралганнары — йорт С.сы (P. domestica) һәм кыргый сливалар — С.ның күгән б-н гибридлары. Иделнең уң як ярында «Скороспелка красная» һәм «Тернослива волжская» сортлары үстерелә. Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының Тәмте бакчачылык бүлегенең селекция эше нәтиҗәсендә С.ның һәм эре җимешле күгәннең яңа сортлары барлыкка килә: «*Сверххранняя*», «Казанская», «*Ракитовая*», «*Тәмте Ренклоды*»,



«Волжанка», «Память Хасанова», «Татарская жёлтая», «Теньковская голубка», «*Теньковская синяя*». Ш.у. халык селекциясенең иң яхшы сортлары «Скороспелка красная» һәм интродуцияләнгән «Евразия 21» үстерелә. С. үстерү өчен иң яхшы шартлар Татарстанның Көньяк-Көнбатыш өлеше — Идел алдында. С.ны, гадәттә, яз көне (апрель ахыры – май башында) утырталар. Бөре ялгап һәм яшел чыбыкчалардан үрчетәләр. Күмәк һәм йорт яны бакчаларында үстерәләр. С.ның корткычлары: слива җимешашары, слива кара кисмәне, слива гөбләләре, калканчыклар, слива юанаяклары һ.б. Авырулары: монилиоз, яисә соры черек, клястероспориоз яисә яфракларның тишекле таплылыгы; камедь агу (гоммоз), С. тутыгы һ.б.

*Әд.:* Плодоводство. М., 1979; Фруктовый сад Татарстана. К., 2005.

*В.А.Наумов, Л.А.Севастьянова.*

**«СЛО́ВО АГИТА́ТОРА»**, журнал; к. «*Офык*».

**«СЛО́ВО КОММУНИ́СТА»** («Коммунист сүзе»), *Россия Федерациясенең коммунистлар партиясе* Татарстан региональ бүлеге г-тасы (РФ КП ТРБ). 1993 елның февраленнән ТР Коммунистлар оешмасы (ТРКО), 1993–2002 дә — ТР Коммунистлар партиясе (ТРКП), 2002–03 тә РФ КП ТРБ басмасы буларак чыга. 1993–95 тә редакция Апас авылында, 1995–2003 тә Казанда эшли. Төрле еллардагы баш мөхәррирләре — Н.К.Столярова, В.Козлова, В.И.Чернова. 1993 тә ай саен чыга, аннары — аена 2–3 тапкыр; кайвакыт, акча җитмәү сәбәпле, чыгудан туктап тора. 1993 тә газетаның татарча версиясен — «Коммунист сүзе»н бастырып карыйлар, әмма аның 1 саны гына басыла. «С.к.» бушлай һәм яздыру юлы б-н таратыла. РФ КП ТРБ партия әгъзалары арасында газетага яздыруны оештырып карый, әмма газетаны тарату мәсьәләләрен хәл итә алмый. Анда, нигездә, Татарстан һәм Россиянең сәяси, социаль-икътисади проблемалары күтәрелә. Өстенлекле юнәлеш — респ-ка һәм федераль башкарма хакимият җитәкчелеген кискен тәнкыйтьләү. ТРКО/ТРКП/РФКП/ТРБ материаллары (съездлар, конференцияләр, реском пленумнары хисаплары һәм карарлары), Татарстан коммунистларының публицистик материаллары, Россия коммунистик басмаларыннан күчереп басылган язмалар дөнья күрә. Беренче елларда редакция ТРКО/ТРКП эчендә төрле идея-сәяси агымнар яшәп килү б-н аңлатылган көнүзәк мәсьәләләр буенча фикерләр спектрын (дөньяга коммунистик караш кысаларында) чагылдырырга омтыла. Гомумроссия коммунистлар партияләре һәм хәрәкәтләре, беренче чиратта Коммунистик партияләр союзы; КПСС, Россия коммунистик эшчеләр партиясе, «Хезмәтчел Россия» хәрәкәте эшчәнлеге актив яктыртыла, беркадәр РФ Коммунистлар партиясенә (РФКП) дә урын бирелә. 1990 елларның икенче яртысыннан редакцияләү сәясәте ортодоксальрәк була башлый, бу исә материалларның сыйфаты начарлануга, үзенчәлекле язмалар азаюга, башка басмалардан күчереп бастыруның артуына китерә. «С.к.» тар партияле г-тага әверелә, өстәвенә даими финансланмый. 2003 тә чыгудан туктый. Аңа алмашка яңа басма — «Казанская искра» (РФКП Казан шәһәр ком-ты органы) газета-листовкасы килә. 2006–07 дә «С.к.» исеме б-н партия газетасы басмасын яңартуга омтылыш була, әмма берничә саны гына дөнья күрә.

*Әд.:* Т е р е н т ь е в а И.В., Б е л я к о в Р.Ю., С а ф а р о в М.Ф. Республика Татарстан: политические партии, движения, лидеры. К., 2003.

*М.Ф.Сәфәров.*


**СЛУГИНО́В** Николай Петрович (2.10.1854, Түбән Новгород ш. — 10.2.1897, Казан), физик, физика д-ры (1884). Петербург ун-тын тәмамлаганнан соң (1877), шунда ук эшли (бүленеп: 1877–81елларда С.-Петербургның Введение гимназиясендә). 1884 тән Мәскәү техник уч-щесе профессоры. 1886 дан Казан ун-тының физика һәм физик геогр. каф. профессоры, бер үк вакытта, 1888–93 тә, ун-тның метеорология һәм магнит обсерваторияләре, ш.у. физик геогр. кабинеты мөдире. Хезмәтләре электр күренешләренә һәм электролитлар теориясенә карый. С., беренче булып, электродларның электролиз вакытында яктыруын тикшерә. Алюминийны корунд катылыгына ия булган сусыз чыдам глинозём катламы б-н каплау ысулын ача. Электролиз вакытында элементның электр йөртү көченә шул тирәлек токларының тәэсирен аңлата.

Х е з м.: О поляризации ртутных электродов // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. 1877. № 9; Теория электролиза // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. 1881. № 13; Опыты с током большой частоты // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. 1894. № 26.

**СМА́ГИН** Леонид Максимович (24.10.1932, Түбән Идел краеның Вольск ш.), партия хезмәткәре. Мәскәү торф ин-тын тәмамлый (1957). «Бөгелмәнефть» нефть промыселы идарәсендә (НПИ), «Лениногорск» НПИдә,

«Иркеннефть» НПИдә (Лениногорск ш.) инженер-геолог, геолог, өлкән геолог булып эшли. КПССның Лениногорск шәһәр ком-ты 2 нче секретаре (1966–68), 1 нче секретаре (1968–79). КПССның Татарстан өлкә ком-ты секретаре (1979–86), 2 нче секретаре (1986–87), 1987–89 да СССР Нефть продуктлары б-н тәэмин итү Дәүләт ком-ты рәисе, минераль ашламалар җитештерү буенча министр урынбасары. 1971–90 да ТАССР ЮС депутаты. Өч Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**СМАГУ́ЛОВ** Бәхетҗан Жумашкан улы (4.11.1965, Казакъстан ССР, Семипалатинск өлкәсенең Чарск ш.), балет артисты, педагог, Казакъстан һәм ТРның халык артисты (1993, 2003). 1984 елда Ленинград акад. хореография уч-щесен тәмамлый. 1984–94 тә Абай исем. Казакъ опера һәм балет театрының балет солисты (Алма-Ата), 1989 дан 1994 кә кадәр эзлекле рәвештә АКШ һәм Япониянең балет труппаларында контракт буенча эшли. 1994–2009 да Татар опера һәм балет театрында балет солисты, 2009 дан педагог-репетитор. 2012 дән Пермь шәһәрендә яши. Көчле героик-романтик амплуадагы биюче: Базиль, Солор («Дон Кихот», «Баядерка», Л.Минкус), Али һәм Бирбанто («Корсар», А.Адан), Вакх («Вальпургия төне», «Фауст» операсыннан, Ш.Гуно) һ.б. Шуның б-н бергә күпьяклы башкаручы; уңышлы чыгыш ясаган лирик-романтик партияләре — Альберт («Жизель»,



Б.Ж. С м а г у л о в Бирбанто ролендә («Корсар», А.Адан).

А.Адан), Зигфрид, Дезире, Щелкунчик («Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл», «Щелкунчик», П.Чайковский), ш.у. көлкеле партияләре — Шут («Аккош күле», П.Чайковский), Пан («Вальпургия төне», Ш.Гуно) һәм драматик рухтагы Хозе («Кармен-сюита», Ж.Бизе-Р.Щедрин), дуэт биюендә бик яхшы партнёр. Париж (Франция, 1988, ике номинациядә 2 көмеш медаль), Хельсинкида (Финляндия, 1991, көмеш медаль), Осака шәһәрендә (Япония, 1991, бронза медаль) халыкара балет конкурслары лауреаты.

*Әд.:* Г о р ш к о в В.Н. Солисты Татарского балета. К., 2000; К а д ы р о в а А. Бахытжан Смагулов: Я достойно завершил карьеру. Рождение династии // Вечерняя Казань. 2006. 15 апр.; Народные артисты СССР, РФ, РТ. К., 2011.

**СМА́КОВ** Илфак Мөҗип улы (2.1.1940, БАССРның Чакмагыш р-ны Рапат а. — 27.5.1993, Уфа ш.), җырчы (баритон), БАССРның халык, РСФСРның атказ. артисты (1985, 1989). 1963 елда Уфа сәнгать уч-щесенең вокал бүлеген тәмамлый. 1963–91 дә Башкорт филармониясе солисты, концерт эшчәнлеге алып бара. Матур, көчле тавышка ия. Аның башкаруы тәэсирле, хисле һәм күтәренке рухлы булуы б-н аерылып тора. С.ның концерт репертуарын башкорт композиторларының вокаль әсәрләре; башкорт, татар һәм рус халык җырлары, классик вокаль репертуар әсәрләре тәшкил итә. С. башкаруында М.Мозаффаровның «Кайда да йөрәктә», Ә.Бакировның «Әйткән идең», Р.Хәсәновның «Сиңа тагын мин бер киләм әле», «Үз ягыма кайтсам», В.Хәбисламовның «Җиз кыңгырау моңнары» җырлары аеруча популяр була.


*Әд.:* Вокальная школа Миляуши Муртазиной. Уфа, 2001.

**СМА́КОВ** Ринат Миргалим улы (10.3.1940, БАССРның Благовар р-ны Иске Абзан а.), хокук белгече, РСФСРның атказ. юристы (1991). Казан ун-тын тәмамлый (1967). 1967–69 елларда Казанның халык судьясы. 1969–72 дә ТАССР Югары мәхкәмәсе әгъзасы. 1972–93 тә РФ Югары мәхкәмәсе әгъзасы, 1993 тән рәисе урынбасары. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**СМӘЙ́Л** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 24 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шушма елгасы буенда. 2010 елда 791 кеше (татарлар) яши. Халыкның төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, урындык һәм кәрзин үрү, тарантас ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.дә мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2150,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Сизнер волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1859 да — 1467, 1884 тә — 1657, 1905 тә — 1840, 1926 да — 1792, 1938 дә — 1572, 1949 да — 942, 1958 дә — 804, 1970 тә — 998, 1979 да — 894, 1989 да — 781, 2002 дә — 804 кеше. С. тирәсендә 16 йөзнең 1 нче яртысы эпиграфик истәлекләре — кабер ташлары сакланган.

**СМЕЛКО́В** Вячеслав Михайлович (25.1.1938, Биектау р-ны Бимәр а.), геолог-нефтьче, геол.-минерал. фән. канд. (1980), ТРның атказ. геологы (1993), РФнең атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1960), шунда ук эшли (бүленеп: 1965–68 дә Казан пед. ин-тында), нефть һәм газ геологиясе каф. мөдире (1987–2008). Хезмәтләре углеводородлар геологиясенә карый. Урта ташкүмер системасы утырмаларында нефть ятмаларының урнашу закончалыкларын эшли һәм нигезли, Татарстан терр-ясендәге углеводород чыганакларын фаразлый һәм аларны эзләүдә тәкъ-



Б.Ж. Смагулов.

димнәр бирә. Геология, нефть һәм газ эшкәртү проблемалары буенча РФА Гыйльми советы әгъзасы (1996 дан). «Геолог-нефтьчеләр — Казан университетын тәмамлаучылар» («Геологи-нефтяники — выпускники Казанского университета», 2005) библиография сүзлеген төзүчеләрнең берсе. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Стратегия и тактика освоения ресурсов на поздней стадии разведки // Современные проблемы геологии нефти и газа. М., 2001; Нефтегазоносность Республики Татарстан: Геология и разработка нефтяных месторождений: В 2 т. К., 2007 (автордаш).

**СМЕРКО́ВИЧ** Соломон Львович (1.7.1908, Кострома ш. — 15.9.1988, Казан), суднолар төзү инженеры, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1949). Горький индустриаль ин-тын тәмамлый (1938). Хезмәт эшчәнлеген 1925 елда хезмәт инспекциясендә эш башкаручы булып башлый (хәзер Түбән Новгород өлкәсенең Ветлуга ш.). Соңрак караучысыз калган балалар йортында пионервожатый (хәзер Түбән Новгород өлкәсенең Ветлуга өлкәсе Бемицово а.). 1927–30 да өлкә хезмәт бүлегендә эшли (Ленинград). 1938–58 дә А.М.Горький исем. заводта (Яшел Үзән ш.): мастер ярдәмчесе, мастер, участок, цех, заводның җитештерү башлыгы. 1958–61 дә ТАССРның 1 нче машиналар төзү идарәсендә башлык урынбасары. 1961–63 тә матди-техник тәэминат идарәсендә башлык урынбасары (Казан). 1963–68 дә «Газоаппарат» з-ды директоры (Казан). Дәүләт бүләге суднолар төзүне тамырдан камилләштерүдә катнашканы өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**СМЕ́ТОВ** Пётр Кузьмич (3.12.1930, Түбән Новгород крае, Урень р-ны Б.Горево а. — 16.10.1997, Казан), вет. табибе, вет. фән. д-ры (1982), проф. (1984), ТАССРның, РФнең атказ. фән. эшлеклесе (1987, 1996). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1955), Горький өлкәсе Константиново р-нының өлкән вет. табибе булып эшли. 1958–60 елларда Мәскәү Хәрби округының «Сейла» с-зында, 1960–62 дә Горький өлкәсенең Вача р-ны «Казаковский» с-зында вет. табибе. 1962–84 тә Казан вет. ин-тының вет. санитариясе бүлеге мөдире. 1984–97 дә Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тының экологик токсикология бүлеге мөдире. Фәнни тикшеренүләре сыйфатлы терлекчелек продукциясе алу максатыннан, терлек организмының химик һәм биол. агулы матдәләргә каршы торучанлыгын арттыру мәсьәләләренә; агулы матдәләр ин-

дикациясе һәм аларның терлек организмына тәэсире механизмын өйрәнүгә; интоксикация очрагында терлекләрне дәвалау чараларын һәм ысулларын эшләүгә карый. Уйлап табуга 98 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Влияние ультрафиолетового облучения на динамику изменений живого веса, морфологических и биохимических показателей крови в онтогенезе // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1965. Т. 94; Роль митоксинов в этиологии алимен-токсикозов животных // Рациональные методы профилактики, диагностики и терапии незаразных болезней животных. К., 1993.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*К.Х.Папуниди.*

**СМИРНО́В** Александр Афанасьевич (2.11.1946, Теләче р-ны Теләче а.), генерал-майор (1993), тарих фән. канд. (1997). ТАССР ЮС Президиумы исем. Казан югары танк командирлары уч-щесен (1966), В.И.Ленин исем. Хәрби-сәяси академияне (Мәскәү, 1978) тәмамлый. 1967–77 елларда Совет Армиясе частьларында һәм берләшмәләрендә комсомол эшендә. 1977–89 да СССР Кораллы көчләре сәяси оешмаларында җитәкче вазифалар башкара. 1990–93 тә Ерак Көнчыгыш Хәрби округында, Хәрби совет әгъзасы, сәяси бүлек башлыгы, хәрби-сәяси бүлек башлыгы, гомумгаскәр армиясе командующие урынбасары, хезмәт итүчеләр составы б-н эшләү буенча командующий ярдәмчесе. 1993 тән РФ Кораллы көчләрендә тәрбия эшләре буенча тыл башлыгы ярдәмчесе, РФ Президенты киңәшчеләре аппараты, РФ Президенты киңәшчеләре эшчәнлеген тәэмин итү һ.б. эшчәнлекләр буенча департаментлар башлыгы, бер үк вакытта РФ Президенты каршындагы гражданлык җәмгыяте һәм кеше хокуклары ин-тларын үстерү Советы башлыгы. «Хәрби хезмәтләре өчен», Дуслык, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗәдәге «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.


**СМИРНО́В** Александр Васильевич (16.11.1857, Сембер губ. — ?), дин белгече, җәмәгать эшлеклесе, дин белеме д-ры (1900). Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1884), Вольск руханилар семинариясендә укыта (Саратов губ.). 1889 елдан Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында; 1891 дән Казан руханилар академиясендә, экстраординар проф. (1896); бер үк вакытта, 1896–1912 дә, Казан ун-ты һәм Казан вет. ин-тында православие дине белеме каф. профессоры. Университет чиркәве башлыгы, протоиерей (1896 дан). 1906–07 дә «*Церковно-общественная жизнь*» ж-лын нәшер итә. 4 нче Дәүләт Думасы депутаты (1912–17). Хезмәтләре Библия тарихына, дин гыйлеменә, диннәр тарихына карый.

Хезм.: Мессианские ожидания и верования иудеев около времён Иисуса Христа. К., 1899; Социализм в оценке Ф.Достоевского. К., 1907; Курс истории религий. К., 1908; Будущность христианства. П., 1914.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1.

**СМИРНО́В** Александр Павлович (1916–1988, Казан), генерал-майор (1964). 1941 елның июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, НКВД гаскәрләренең 175 нче Урал укчы дивизиясендә сәяси бүлек башлыгы. Дон, Үзәк һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Сталинград сугышында (1942–43), Орёл (1943), Белоруссия (1944), Варшава-Познань (1945), Берлин (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1955–58 дә суворовчыларның Ленинград хәрби уч-щесендә башлык урынбасары һәм укыту бүлеге башлыгы. 1958–74 тә Казан суворовчылар хәрби уч-щесе башлыгы. 1963–67 дә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Суворов орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**СМИРНО́В** Алексей Петрович (29.5.1899 — 11.3.1974, Мәскәү), тарихчы, археолог, тарих фән. д-ры (1944), проф. (1951), Чуаш АССРның, ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1958, 1959). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1926), Археол. ин-тында эшли, 1957 елдан скиф-сармат археологиясе секторы мөдире, СССР ФА Матди мәдәният тарихы ин-ты директоры урынбасары. Бер үк вакытта, 1951 дән, Дәүләт Тарих музее (Мәскәү) директоры урынбасары һәм Мәскәү ун-ты профессоры. 1933–37 дә *Суар шәһәрлеген* казу эшләренә җитәкчелек итә. 1938–49 да СССР ФА Матди мәдәният тарихы ин-тының С. җитәкчелегендәге экспедициясе тарафыннан *Болгар шәһәрлегендә* археол. казу эшләре уздырыла. Бөек Ватан сугышы башыннан 1942 нең февраленә кадәр Мәскәү халык ополчениесендә катнаша. 1942–44 тә СССРдагы мәдәният истәлекләренә немец-фашист илбасарлары китергән зыянны ачыклау буенча СССР ФАнең Махсус эш йөкләнгән экспедициясендә эшли. 1946–57 дә, Куйбышев археол. экспедициясе җитәкчесе буларак, Куйбышев сусаклагычының су басу зонасындагы тарихи истәлекләрне коткаруда катнаша. 1957–69 да Идел буе археол. экспедициясе җитәкчеләреннән берсе була, Идел буендагы Алтын Урда шәһәрләрен өйрәнү б-н шөгыльләнә. С. Идел буе болгарларының социаль-икътисади һәм сәяси тарихын тикшерүгә, ш.у. Идел буе Болгар дәүләте историографиясенә зур өлеш кертә. Аның тарафыннан беренче булып Идел буе Болгар дәүләте терр-ясен билгеләүгә, аның иҗтимагый-икътисади төзелешенә, болгарларда һөнәрчелек, сәүдә, шәһәрләр, хәрби эшнең үсеш дәрәҗәсенә бәйле бик тә мөһим мәсьәләләр игътибар үзәгенә алына. С. хезмәтләрендә күтәрелгән болгар керамикасын һәм хезмәт коралларын классификацияләү принципларына нисбәтле күп кенә нигезләмәләр, тимерчелек, металлургия, зәркәнчелек үсеше мәсьәләләре хәзерге заман археологлары һәм тарихчылары хезмәтләрендә алга таба үстерелә. С. эшчәнлегендә археол. истәлекләрне саклау проблемасы зур урын били: аның актив булышлыгы б-н 1969 да Болгар тарихи-архит-ра музей-саклаулыгы оештырыла. Хезмәтләре скифлар, Идел болгарлары тарихы һәм мәдәниятенә, Урта Идел буе, Урал алды һәм Урал халыкларының борынгы һәм урта гасырлар тарихын өйрәнүгә карый. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.



Алексей П. Смирнов.

Хезм.: Древняя история чувашского народа (до монгольского завоевания). Чебоксары, 1948; Волжские булгары // Тр. Гос. ист. музея. 1951. Вып. 19; Очерки древней и средневековой истории народов Среднего Поволжья и Прикамья // Материалы и исслед. по археологии СССР. 1952. № 28; Скифы. М., 1966.

*Әд.:* Научное наследие А.П.Смирнова и современные проблемы археологии Волго-Камья: Сб. тез. докл. конф., посв. 100-летию со дня рождения А.П.Смирнова. М., 1999; Овчинников А.В. Древняя и средневековая история Волго-Уралья в трудах советских учёных: А.П.Смирнов. К., 2008.

*А.В.Овчинников.*

**СМИРНО́В** Андрей Иванович (16.9.1893, Казан — ?), гигиена белгече, мед. фән. канд. (1935). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1920), шунда ук гигиена, социаль гигиена (1922–32) кафедраларында эшли, 1932–60 елларда — балалар һәм яшүсмерләр, 1944 тән мәктәп гигиенасы кафедралары мөдире. Бер үк вакытта, 1935–37 дә, ТАССР Социаль сәламәтлек саклау ин-тының гигиена бүлеге мөдире. 1938–40 та Казан ГИДУВының гомуми гигиена кафедрасында, бер үк вакытта, 1938–48 дә, Казан пед. ин-тында, 1948–53 тә Казан ГИДУВының туклану гигиенасы кафедрасында. Бөек Ватан сугышында катнаша: 1941–43 тә госпиталь башлыгы. Хезмәтләре гомуми гигиенага, мәктәп һәм туклану гигиенасына, химия сәнәгате пр-тиеләрендә хезмәт шартларын өйрәнүгә карый. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Физико-химическая обстановка труда в производстве основной химической промышленности ТАССР // Гигиена труда. 1927. № 4; Очерк антропологической деятельности научных учреждений // Рус. антрополог. журн. 1930. Т. 19.

**СМИРНО́В** Аполлон Иванович (13.10.1838, Түбән Новгород губ. Княгинин ш. — 20.4.1902, Казан), философ. Түбән Новгород руханилар семинариясен, Казан ун-тының тарих-филол. ф-тетын тәмамлый (1870). Түбән Новгород шәһәрендәге гимназиядә укыта. 1873 елдан Казан ун-тында, 1881 дән филос. каф. ординар профессоры, 1898 дән атказ. проф., бер үк вакытта, 1897–1901 дә, тарих-филол. ф-теты деканы. Хезмәтләре инглиз философиясе тарихына, эстетика һәм этикага карый.

Хезм.: Философия Беркли. К., 1877; Английские моралисты XVII в. Реформа моральных наук и основание научной этики в Англии. К., 1880; Эстетика как наука о прекрасном в природе и искусстве. К., 1894.

*Әд.:* Радлов Э. А.И.Смирнов // Журн. М-ва нар. просвещения. 1902. Ч. 344; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

**СМИРНО́В** Василий Дмитриевич (28.7.1846, Әстерхан губ., Әстерхан өязе Бирючья Коса а. — 25.5.1922, Петроград), шәркыятьче,

китап гыйлеме белгече, цензор, төрек-татар теле һәм әдәбияты д-ры (1887). Петербург ун-тының Шәрекъ бүлеген тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1884–1922 елларда төрек-татар теле һәм әдәбияты профессоры. Бер үк вакытта, 1880–1905 тә, Петербург цензура ком-тында татар китабы цензоры. Госманлылар империясе һәм Кырым ханлыгы, Төркия һәм төрек әдәбияты тарихы буенча хезмәтләре бар. Цензор сыйфатында үзен кадимче буларак таныта, күп кенә фәнни-популяр һәм матур әдәбиятны, рус классикасы тәрҗемәләрен бастыруны тыя. Полиция департаментына татар әдәбиятындагы күп кенә әсәрләрнең «зарарлы» юнәлеше турында яза, татар телендә вакытлы матбугат оештыруга каршы була. 1885–93 тә «Рус археология җәмгыятенең шәрекъ бүлеге язмалары»нда Россиядәге мөселман әдәбиятына күзәтүләр бастыра (китап белеме буенча әһәмиятле чыганак булып тора).

Х е з м.: Кучибей Гёмурджинский и другие османские писатели о причинах упадка Турции. СПб., 1873; Крымское ханство под верховенством Османской империи до начала XVIII века. СПб., 1887.

*Әд.:* М а ш т а к о в а Е.И. В.Д.Смирнов — исследователь турецкой литературы // Советская тюркология. 1971. № 4; К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; Г а й н у л л и н М.Х. Татарская литература XIX века. К., 1975.

**СМИРНО́В** Виталий Алексеевич (15.7.1939, Хабаровск ш.), авиация технологиясе өлкәсе белгече, техник фән. д-ры (1992), проф. (1992). 1962 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (2009 га кадәр), 1991–2000 дә приборлар һәм автоматлар җитештерү (хәзер — стандартлаштыру, сертификация һәм технол. менеджмент) каф. мөдире. 1995 тән Казан авиация технологиясе фәнни-тикшеренү ин-тының директор урынбасары, 2003 тән ген. директор урынбасары. Хезмәтләре авиация техникасында юка стеналы детальләрне пластик формалаштыру һәм ныгытуга карый.


С. ядрәсыман бәреп форма бирү технологиясенең фәнни нигезләрен эшли, киң фюзеляжлы самолётларда кайма ясап урнашкан детальләрне ныгыту юлларын тикшерә. Самолётның көч төшә торган детальләренә һәм монолит панельләргә форма бирү һәм ныгыту өчен С. тәкъдим иткән технол. процесслар һәм җайланмалар Мәскәү, Казан, Киев, Ульяновск, Ташкент шәһәрләренең авиация з-дларында гамәлгә кертелгән. Уйлап табуга 52 авторлык таныклыгы бар. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Местное упрочнение деталей поверхностным наклёпом. М., 1985 (автордаш); Основы теории и расчёта изготовления деталей методами холодной штамповки. К., 1986 (автордаш).

**СМИРНО́В** Георгий Семёнович (5.5.1914, Казан губ., Мамадыш өязе Албай а. — 2.11.1941, Ставрополь шәһәренең туганнар каберлегендә җирләнә), РФ Герое (8.3.2008, үлгәннән соң), лейтенант. 1935 елда Оренбургта К.Е.Ворошилов исем. 3 нче очучылар һәм күзәтүче очучылар хәрби мәктәбен тәмамлый. 1935 тән Кызыл Армиядә. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 50 нче авиация дивизиясенең 81 нче ерак араларга оча торган бомбардировщиклар авиация полкында звено командиры. Көньяк фронтның очучылар экипажы составында 22 хәрби очыш ясый, дошманның 3 истребителен һәм 4 танкын юк итә. Белая Церковь (Киев өлкәсе) һәм Днепропетровск (Украина ССР) шәһәрләре тирәсендәге һава сугышларында батырлык күрсәтә: 1941 нең 25 июлендәге рейд вакытында С. бомбардировщигы дошманның зенит артиллериясе тарафыннан утка тотыла, әмма бензин багы тишелүгә карамастан, бомбага тотуын дәвам итә һәм дошманның истребителен бәреп төшерә. Сугышчан бурычны үтәп кайтканда дүрт дошман самолёты һөҗүменә очрый, манёвр вакытында тагын бер дошман истребителен бәреп төшерә, зарарланмаган мотор б-н экипаж базага кайта. 1941 нең 20 августында С. самолёты бәреп төшерелә. Командир пешкән тән җәрәхәтләре ала, әмма янучы машинаны үз терр-ясенә кадәр китереп җиткерә; экипажга котылырга мөмкинлек бирә, үзе самолеттан иң соңыннан чыга. 1941 нең 31 октябрь төнендә сугышчан бурычны үтәп кайтып килгән дүрт кешедән торган экипажлы (звено командиры — С.) ТБ-3 самолёты тишкәләнә: төп ягулык багына зыян килә, двигателе һәм радиостанция эштән чыгарыла; бортта көчле янгын чыга; самолёт Орджоникидзе (хәзер Ставрополь) краеның Александровский р-ны Северный авылы янында җиргә утырырга мәҗбүр була. Самолёт көчле томан шартларында җиргә төшә һәм чокыр сөзәклегенә бәрелә. С. экипаж әгъзаларын янучы машинадан алып чыга һәм аларга ярдәм күрсәтә. Үзе яралардан госпитальдә үлә. Ике тапкыр Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә: 1941 дә (исән чакта) һәм 1942 дә. Туганнары (С.ның тол хатыны, аннан соң улы — Г.Г.Смирнов) архивларда югалган документларны эзлиләр (алар 2003 тә РФ Оборона министрлыгының Үзәк архивында табыла). 2008 дә С.ның улы РФ Президенты В.В.Путинга ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. 2008 нең 14 маенда Казанда тантаналы рәвештә Россия Героеның «Алтын Йолдыз»ы С.ның балаларына — улына һәм кызына тапшырыла.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СМИРНО́В** Герман Алексеевич (3.12.1929, Кострома ш. — 4.11.2001, Казан), фтизиатр, мед. фән. д-ры (1970), проф. (1971), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1982). Ярославль мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), Якутия АССРда туберкулёз диспансеры баш табибе булып эшли. 1959 елдан Үзәк туберкулёз ин-тында (Мәскәү). 1962 дән Молдавия туберкулёз фәнни-тикшеренү ин-тында. 1965–2001 дә Казан ГИДУВының фтизиатрия һәм пульмонология каф. мөдире. Хезмәтләре туберкулёзны дәвалауга (химиотерапия), үпкәдәге специфик булмаган авыруларны һәм кискен деструктив үпкә ялкынсынуын антибиотиклар б-н интенсив дәвалау ысулларын гамәлгә кертүгә карый. Татарстан респ-ка фтизиатрлар җәмгыяте идарәсе рәисе (1970 тән). ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.



Г.С.Смирнов.



И.В.Смирнов.

Х е з м.: Препараты ГИНК в терапии больных туберкулёзом. М., 1969; Антибиотикотерапия в пульмонологии. Л., 1987.

**СМИРНО́В** Иван Николаевич (7.1.1856, Казан губ., Царёвококшайск өязе Арино а. — 15.5.1904, Казан), тарихчы, этнограф, рус тарихы д-ры (1884). Рухани гаиләсеннән. Казан руханилар уч-щесендә, Казан руханилар семинариясендә укый. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1878), шунда ук гомуми тарих кафедрасында эшли, проф. (1896 елдан). Хезмәтләре көньяк славяннарның матди һәм рухи мәдәнияте үсешенә, Балкан ярымутравында яшәүче кабиләләрнең иҗтимагый мөнәсәбәтләренә, ш.и. болгар мәдәниятендә төрки элементларны ачыклауга багышлана. Идел буе һәм Урал төбәге фин-угор халыклары (мари, удмурт, мордва) турындагы этнографик хезмәтләрдә С. аларның мәдәниятен һәм көнкүрешен, үткәндә һәм хәзерге вакытта әлеге халыкларның таралышын, аларга төрки-татар мәдәниятенең тәэсирен өйрәнә, тарихи әдәбиятны тикшерә. Идел-Урал төбәгенә фәнни экспедицияләр оештыра. Казан ун-ты Советының 1884 елгы Уставтагы үзгәрешләр өстендәге эшчәнлегендә катнаша, ун-т автономиясе идеясен яклый, Югары уку йорты эшчәнлеге мәсьәләләрен язып чыга. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең актив әгъзасы, даими гыйльми секретаре. «Волжский вестник», «Казанский телеграф» г-талары б-н хезмәттәшлек итә. Казан фәнни-сәнәгать күргәзмәсенең тарихи-этнография бүлеген оештыручыларның берсе (1890). Пермь гыйльми архив комиссиясе әгъзасы, Угор-фин гыйльми җәмгыятенең (Гельсингфорс ш.) шәрәфле әгъзасы. Уваров бүләге лауреаты (1896). ФА, Рус геогр. җәмгыятенең алтын медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Черемисы. К., 1889; Вотяки. К., 1890; Пермяки. К., 1891; Мордва. К., 1892; Очерки истории южных славян: В 3 вып. К., 1900–04.

*Әд.:* Памяти профессора Ивана Николаевича Смирнова. К., 1904; П а х о м о в Ю.В. И.Н.Смирнов в письмах к С.Н.Шубинскому // Биография исследователя как жанр славистики. Тверь, 1991; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

*Р.А.Айнетдинов.*

**СМИРНО́В** Игорь Валентинович (8.12.1926, Саратов ш. — 1.12.1989, Мәскәү), балетмейстер, педагог, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1959), РСФСРның халык артисты (1978), проф. (1978). 1944 елда Мәскәү хореография уч-щесен, 1951 дә Дәүләт театр сәнгате ин-тын (Мәскәү) тәмамлый. 1944–49 да



Л.Е.Смирнова.

Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясе балетмейстеры. Румыния (1953–54) һәм Япония (1963–64) опера һәм балет театрларында педагог һәм балетмейстер булып эшли. 1958–60, 1962, 1964–67 дә — Карелия АССРның Музыка театрында, 1960–61 дә К.С.Станиславский һәм В.И.Немирович-Данченко исем. Музыка театрында (Мәскәү) баш балетмейстер. 1967 дән Мәскәү мәдәният ин-тында хореография каф. мөдире. С.ның балет спектакльләре сюжеты киң үсеш алган драматургиясе, ачык, төгәл хәрәкәтләре, музыкальлеге б-н аерылып тора. Мәскәү, Петрозаводск, Токио театрларында куелган классик балет спектакльләреннән тыш, Мәскәү, Ташкент, Харьков, Бухарест шәһәрләре театрларында сәхнәләштерелгән үзенчәлекле заманча балет спектакльләре куелышлары авторы. Татар опера һәм балет театрында Г.Сисалоның «Кижи легендасы» («Кижская легенда», 1963), Ә.Бакировның «Су анасы» (1970) балетларын куя. ТАССРның Г.Тукай исем. (1973), РСФСРның М.И.Глинка исем. Дәүләт бүләкләре лауреаты (1973, 1986).

Х е з м.: Искусство балетмейстера. М., 1986.

*В.Н.Горшков.*

**СМИРНО́В** Пётр Дементьевич (1745, Казан — 1815, шунда ук), Казан сәүдәгәре һәм җәмәгать эшлеклесе, «хезмәт буенча атаклы граждан». Урта һәм Түбән Идел буенда, Кама алдында, Урал һәм Себердә тукыма, мех, селте-поташ, ашлык б-н сәүдә итә. Казанда Гостиный дворның постау һәм мех рәтләрендә, Проломная урамындагы Икмәк базарының үзе төзегән таш кибетләрендә сәүдә итә. Казан һәм Лаеш өязләрендә (ш.и. Седмиозёрный Пустынендә, Усадта, Борисковода) зур умарталыклары була; бал, май, җиләк-җимеш, ш.у. иконалар һәм дини эчтәлекле китаплар б-н сәүдә итә. 1774–77 елларда Казан шәһәр магистраты бургомистры, С. дәверендә Е.И.Пугачёв гаскәрләре һөҗүменнән соң шактый җимерелгән Казан шәһәре төзекләндерелә. 1794–96 да шәһәр Думасы башлыгы, 1800 дә икенче тапкыр шәһәр башлыгы итеп сайлана (4 айдан соң, авыру сәбәпле, эштән азат ителә). Губерна магистраты каршындагы вөҗдан мәхкәмәсе утырышчысы (1782–86), шәһәр вөҗдан мәхкәмәсе судьясы. Җәмәгать тәрбиясе приказына зур күләмдә иганә кыла. Варислары булмый, вафатыннан соң барлык мөлкәте шәһәр милкенә күчә.

*Әд.:* С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Л.М.Свердлова.*

**СМИРНО́ВА** Вера Николаевна (26.8.1915, Петроград губ., Луга өязе Островно а. — 9.2.1996, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1973), проф. (1975). Ленинград ун-тын тәмамлый (1940). 1941–42 елларда Свердловск өлкәсендә Криулино урта мәктәбендә укытучы, Красноуфимск р-ны халык мәгарифе бүлеге инструкторы. 1943 тән Мордва АССРның Саранск шәһәрендә: Укытучылар белемен күтәрү ин-тында фәнни хезмәткәр, 1944 тән Саранск пед. уч-щесендә укытучы, 1945 тән ВКП(б)ның Мордва өлкә ком-ты каршындагы партия мәктәбендә. 1948–50, 1954–78 дә Казан ун-тында (бүленеп: 1950–53 тә Будённый р-ны Иске Шәйморза урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы). 1978–82 дә Политехник ин-тының (Братск ш.) иҗтимагый фәннәр каф. мөдире. 1982 дән Казанда яши. Хезмәтләре 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башы хатын-кызлар һәм студентлар хәрәкәте тарихына карый.

Х е з м.: Студенческое движение в Казанском университете в 1887 г. // Вопр. истории. 1949. № 10; Женщины Татарии в борьбе за власть Советов. К., 1963; Женщины Татарии на трудовом фронте в период гражданской войны. К., 1973.

*Әд.:* Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Биобиблиогр. словарь. К., 1999.

*Р.Х.Әхмәтҗанов.*

**СМИРНО́ВА** Елизавета Михайловна (17.4.1928, Чистай кантоны Аксубай а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры, проф. (1982), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1989). Казан ун-ты тарих-филол. ф-тын тәмамлый (1951), шунда ук политэкономия кафедрасында эшли (1952 дән). 1966–80 елларда Казан химия-технол. ин-тында, ин-тның Түбән Кама ф-лының әзерлек бүлеге мөдире (1970–73). 1980–89 да Казан төзүче инженерлар ин-тының политэкономия каф. мөдире. 1989–97 дә Саратов икътисад академиясендә политэкономия каф. профессоры. 1997 дә Казан кооперация ин-тының (Мәскәү кулланучылар кооперациясе ун-ты ф-лы) икътисад һәм оештыру каф. мөдире. Хезмәтләре базар икътисады шартларында эшче көчләрне яңадан торгызу, хезмәт ресурсларын оештыру һәм файдалануга карый. Медальләр б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Концептуальное решение рационального использования трудовых ресурсов в условиях разгосударствления и приватизации // Вопросы занятости в условиях рынка. Тамбов, 1994; Кадровая политика и её реализация в потребительской кооперации Татарстана // Потребительская кооперация: проблемы и пути решения. К., 2002 (автордаш); Региональная занятость и её тенденции // Потенциал кооперации: наука и практика. Ижевск, 2003. Вып. 2 (автордаш).

*Ф.С.Зыятдинов.*

**СМИРНО́ВА** Любовь Евгеньевна (16.7.1944, Юдино штп), химик, җайланмалар аппаратчысы, Соц. Хезмәт Герое (1981), СССРның мактаулы химигы (1978). Техник уч-щене тәмамлаганнан соң (1963), «Казаноргсинтез» АҖнең «Этилен» з-дында: газ аеру цехында аппаратчы (1963–89), заводның профсоюз ком-ты рәисе (1989–2004). С. инициативасы б-н цехта хезмәт күрсәтү зонасын 7 эш урынына кадәр киңәйтеп, хезмәтне оештыруга алдынгы алым кертелә. Смена йөкләмәләрен 105–110% ка үти. С. эшләгән смена коллективы 1976–80 дә 234 *т* углеводород чималы, 146 мең *кВт/сәг* электр һәм 290 *Гкал* җылылык энергиясен экономияли. Герой исеме производствода ирешкән уңышлары, 10 нчы бишьеллык (1976–80) планын һәм соц. йөкләмәләрне вакытыннан алда үтәгәне өчен бирелә. КПССның 27 нче съезды делегаты (1986). 1980–90 да РСФСР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә. «Казаноргсинтез» АҖ тарихы музеенда С.га багышланган экспозиция бар.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Г у р ь я н о в а Р. Народный избранник // Коммунист Татарии. 1985. № 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**СМОЛДЕЯ́РОВО** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 95 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. П.В.Щетинкин йорты — 19 йөзнең 2 нче яртысы архит-ра истәлеге. 1565–68 дән мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.да таш Казан-Богородица чиркәве (1781 дә төзелгән агач



Лаеш районының Смолдеярово авылы. Казан-Богородица чиркәве. 1902–05.

чиркәү урынында 1902–05 тә таштан салына; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1883 тә ачыла), 3 җил тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 601,33 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Чырпы волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 130 ир-ат; 1859 да — 523, 1897 дә — 657, 1908 дә — 670, 1920 дә — 888, 1926 да — 947, 1938 дә — 853, 1949 да — 491, 1958 дә — 313, 1970 тә — 256, 1979 да — 147, 1989 да — 86, 2002 дә — 36 кеше.

*Әд.:* История Лаишевского края. Чебоксары. 1997.

**СМОЛЕ́НСКИЙ** Степан Васильевич (8.8.1848, Казан — 20.2.1909, Түбән Новгород губ. Васильсурск ш.), композитор, педагог, хор дирижёры, музыка белгече. 1872 елда Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлый, 1875 тә, үзлегеннән укып, тарих-филол. ф-тына имтихан тапшыра. Музыка белемен үзлегеннән, бала вакытыннан чиркәү хорларында җырлап үзләштерә. 1875 тә Казан укытучылар семинариясендә чиркәү җыры һәм география укыта. Бер үк вакытта, 1879–89 да, Казан ун-ты студентларының чиркәү хоры б-н җитәкчелек итә. 1889 дан Мәскәү чиркәвендә җырлау буенча синод уч-щесе директоры, бер үк вакытта Мәскәү консерваториясе профессоры. 1901–03 тә С.-Петербургта Патша сарае каршындагы капелла директоры. 1904–07 дә Борынгы язмаларны сөючеләр җәмгыяте рәисе. Греция һәм Болгариядә 2 ел музыка буенча борынгы кулъязмаларны җыя. 1907 дә хосусый Регент уч-щесен оештыра. *Ильминский системасы* буенча укытуны яклый, укытучылар семинариясендә С. тарафыннан Идел буе халыклары, ш.и. татар телләрендә чиркәүдә җырлау системасы эшләнә (хәзер дә файдаланыла). Укытучылар семинариясендә һәм синод уч-щесендә аның тарафыннан чиркәү хоры җырына укытуның үзенчәлекле һәм нәтиҗәле методикасы төзелә. С. тарафыннан укытучылар семинариясе өчен төзелгән чиркәү хоры җыры курсы (1 нче басмасы — 1879 да, тулыландырылган 2 нчесе — 1885 тә) 1917 гә кадәр төрле дәрәҗәдәге югары уку йортларында киң кулланыла, 12 тапкыр кабат басыла. С. хор өчен ектения һәм стихира эшкәртмәләре, ш.у. бу жанрда үзе язган әсәрләре б-н билгеле (чиркәү хезмәтләрендә бүгенге көнгә кадәр кулланыла). Борынгы рус чиркәү музыкасы тарихы буенча хезмәтләр, борынгы музыка кулъязмаларының библиографик тасвирламалары авторы. «Александр Мезенц картның чиркәү җырлары әлифбасы» («Азбука знаменного пения старца Александра Мезенца», 1888) — аеруча нәтиҗәле хезмәтләреннән берсе, ул крюк семиографиясе (чиркәү җырларының язма истәлекләре) нигезләренә багышлана. Анда рус чиркәү музыкасы тарихы яктыртыла һәм 12 йөздән башлап борынгы рус дини җырларының төп үрнәкләре бастырып чыгарыла.

Х е з м.: О древнерусских певческих нотациях: Ист.-палеогр. очерк. СПб., 1901; В защиту просвещения восточно-русских инородцев по системе Н.И.Ильминского. СПб., 1905.


*Әд.:* С о л о в ь ё в Н.Ф. Труды С.В.Смоленского в области изучения русского церковного пения. К., 1908; Степан Васильевич Смоленский. Воспоминания: Казань, Москва, Петербург. М., 2002.

**СМОЛЕ́НЦЕВ** Александр Геннадьевич (6.12.1954, Алексеев р-ны Алексеев а.), спортчы (авиамодель спорты), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1979). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1983). Спорт б-н 1968 елда Татарстан ДОСААФында шөгыльләнә башлый (тренеры — Л.Т.Алдошин). СССР (1980, 1982, 1985–86, 1990–91), РСФСР, Россия (1972, 1978–82, 1984, 1988–89, 1991, 1994, 1997–98) чемпионы; халыкара ярышларда җиңүче (1979, Болгария); СССР, Россия Кубокларында медаль алучы һәм берничә тапкыр җиңүче, дөнья (1979, 1981, 1983), СССР, Россия (1979, 1981–83, 1985, 1995, 1998) рекордчысы; радио б-н идарә ителүле самолётлар, гидро- һәм электросамолёт һәм планёр модельләренең ераклыкка, озынлыкка һәм тизлеккә дөнья чемпионатларында катнаша (Россия җыелма командасы составында 1993, 1995, 1997, 1999). 1979–2003 тә Казан авиация ин-тында, авиамодель лаб-ясе җитәкчесе (1993 тән). 2003–05 тә Казан хакимияте каршындагы Балалар техник иҗаты үзәге лаб-ясе җитәкчесе, 2005 тән ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Респ-ка мәктәптән тыш эшләр үзәгендә методист. Казанның 35 нче мәктәбендә авиамодель түгәрәген алып бара. ТР Авиамодель спорты федерациясе рәисе (1987–2002). Шәкертләре, укучылары арасында бөтенроссия ярышларында медаль алучылар А.Ш.Гафиятуллин, И.Д.Григорьев, А.О.Царёв. Медаль б-н бүләкләнә.

**СМОЛЕ́НЦЕВ** Владислав Павлович (5.8.1936, Мари АССРның Мари-Төрек р-ны Нартасс а.), машиналар төзү технологиясе өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1976), проф. (1980), РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1982), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (1998). 1960 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1959–69 да Мәскәү авиация технологиясе һәм җитештерүне оештыру фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында эшли, 1969–79 да Казан химия-технол. ин-тының машина детальләре каф. мөдире. 1979 дан Воронеж техник ун-тында, механика һәм машиналар төзү ф-ты деканы (1980–83). Хезмәтләре материал эшкәртүнең электрофизик һәм электрохимик алымнарына карый. С. профильсез электрод б-н электроэрозион эшкәртү технологиясен, адаптив идарә системасы ярдәмендә үлчәмнәр буенча электрохимик эшкәртү җайланмасын, махсус техника җитештерү технологияләрен (РФ Хөкүмәте бүләге, 2000) эшли. Хезмәтләре сәнәгатьнең төрле тармакларында гамәлгә кертелгән. Вак серияләрдә чыгарыла торган 5 станок моделен төзи. Уйлап табуга 125 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсы медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Технология электрохимической обработки внутренних поверхностей. М., 1983; Управление качеством. М., 2005 (автордаш).

**СМОЛЕ́НЦЕВ СӘҮДӘ́ ЙОРТЫ́**, Казандагы архит-ра истәлеге; беренче катында кибетләре булган табышлы йорт үрнәге. 1869–73 елларда Университет һәм Зур Проломный (хәзерге Бауман) урамнары чатында Ж.Усмановның ике катлы йорты төзелә (к. *Усмановлар*). 1899 да аны яңа хуҗалар — сәүдәгәрләр Е.С.Смоленцев һәм Н.П.Шмелёв өчен үзгәртеп корыла. Өске өлешендә «Төньяк номерлары» кунакханәсе, аста «И.В.Савиных һәм П.П.Шмелёв» сәүдә йортының «Чәй» кибете ачыла. Планда Г-рәвешендәге өч катлы, почмак өлешле яссы ризалитлы биек, дүрткырлы мичкәсыман гөмбәзле һәм мезонинлы йорт. «Чәй» кибетенең ишеге бинаның почмак ягында урнаша, икенче каттагы купшы итеп чүкеп бизәлгән челтәрле балкон ишекнең түбәсе булып тора. 1909–10 да «Е.С.Смоленцев һәм Н.П.Шмелёв варисларының Казандагы сәүдә йорты» хуҗаларының заказы б-н арх. В.А.Трифонов проекты буенча модерн элементлары кергән эклектик формаларда табышлы йортның дүрт катлы икенче бинасы төзелеп бетә (беренчесе б-н кушыла). Төп фасадтагы ризалитларны каплаган «Чәй» кибете өстендәге гөмбәз төсле 2 зур гөмбәз аның «визит карточкасы» булып тора. Чиктән тыш зур гөмбәзләр, турыпочмаклы биек тәрәзәләр, икенче һәм өченче катлар фонында өч кырлы эркерлар, зур чыгынтылы яссы кәрнизләр һәм фасадның



Смоленцев сәүдә йорты. Казан. 1899, 1909–10. Архитекторы В.А.Трифонов. Хәзерге күренеше.

башка өлешләре модерн стилендә башкарылган. Ике бина бербөтен буларак эшли. Совет чорында биредә «Совет» кунакханәсе, учреждениеләр һәм кибетләр урнаша. Казан шәһәренең борынгы үзәген реконструкцияләү буенча Федераль программа нигезендә 2004 тә ике бина да яңартыла. Тышкы диварлар саклана, урам фасадлары реставрацияләнә, «Шаляпин Палас Отель» («Shalyapin Palace Hotel») кунакханәсен урнаштыру өчен элекке биналар стилендәге яңа корпусның ишегалдындагы фасады яңача планлаштырылган янкорма төзелә. Комплексның яңа исеме Ф.И.Шаляпинның янәшәдәге Богоявление чиркәвендә чукындырылуы б-н бәйле.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982. *Х.Г.Надыйрова.*

**СМО́ЛИН** Виктор Фёдорович (29.3.1890, Пермь губ., Екатеринбург өязе Верхне-Баранчанск заводы — 27.10.1932, Пятигорск ш.), археолог, тарихчы. Томск гимназиясен тәмамлаганнан соң (1909), Казан (1909–11, 1914–18), Лейпциг (1911–13) һәм Галле (1913–14) ун-тларында укый. Германиядә Төньяк Кара диңгез яны антик полислары сәүдә-икътисад тарихы өлкәсендә махсус уку-өйрәнү үтә; Беренче бөтендөнья сугышы башлану сәбәпле, С. докторлык диссертациясен яклый алмый кала. Казанга кайткач, ул антик чор һәм скифлар тарихына һәм археологиясенә багышланган тикшеренүләрен

дәвам итә. С.ның студент елларында язылган «Әдәби һәм археологик истәлекләр буенча Пантикапей» («Пантикапей по литературным и археологическим памятникам», 1915) һәм «Болгар соңгы 40 еллык тикшеренүләр яктылыгында » («Болгары в свете исследования за последние 40 лет», 1917) хезмәтләре Казан ун-тының алтын медальләренә лаек була. 1918–20 елларда Томск шәһәре гимназиясендә һәм ун-тында укыта. Томск шәһәрендә Себерне өйрәнү ин-тын оештыруны башлап йөрүчеләрнең берсе. Бер үк вакытта Көнбатыш Себернең археол. картасын төзү эшенә җитәкчелек итә. 1920 нең көзеннән Казан ун-ты укытучысы һәм Шәрекъ академиясенең археол. каф. профессоры. 1922–29 да Көнчыгыш пед. ин-тында көнчыгышны өйрәнү бүлегенең археол. каф. мөдире. Бер үк вакытта Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте, Татарларны өйрәнү фәнни җәмгыяте әгъзасы. Болгарда, Казанда, Балымер шәһәрлегендә, Морквашино каберлегендә, Чуаш АССРда (анда беренче мәртәбә *Абашево культурасын* аерып күрсәтә) археол. тикшеренүләр алып бара. СССР археологларының 2 нче конференциясендә катнаша (Керчь ш., 1926). 1929–31 дә Херсонес музей-саклаулыгы директоры (Севастополь ш.). 1931 нең февралендә, контрреволюцион эшчәнлектә гаепләнеп, кулга алына, мартта азат ителә. 1931–32 дә Пятигорск төбәкне өйрәнү музее фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре Урта Идел буе һәм Төньяк Кара диңгез яны археологиясен, борынгы һәм урта гасырлар тарихын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: О передвижении геродотовских скифов в Переднюю Азию. К., 1915; К вопросу о происхождении народности волжско-камских болгар: Разбор главнейших теорий. К., 1921; Археологический очерк Татреспублики // Материалы по истории Татарии. 1925. Вып. 2; Абашевский могильник в Чувашской республике: Обзор археол. раскопок в 1925 г. Чебоксары, 1928.

*Әд.:* М и х а й л о в В.П., К у з ь м и н ы х С.В. В.Ф.Смолин и Абашево: К истории археол. изучения Чувашии // Абашевская культурно-историческая общность: Истоки, развитие, наследие. Чебоксары, 2003; К у з ь м и н ы х С.В. Виктор Фёдорович Смолин. 1890–1932. К., 2004.

*С.В.Кузьминых.*

**СМО́ЛЬСКИЙ** Бекир Михайлович (12.7.1913, Минск — 18.9.1982, шунда ук), термофизик, техник фән. д-ры (1958), Белоруссия ССР ФА мөхбир әгъзасы (1967). Польша-Литва татарларыннан. 1935 елда Белорус политехник ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (1946 дан). 1958 дән Белоруссия ССР ФАнең Энергетика ин-тында: җылылык һәм масса алмашу лаб-ясе мөдире, директор урынбасары (1959 дан), проф. (1961). 1971 дән Белоруссия ССР ФАнең Җылылык һәм масса алмашу ин-тында термоаэродинамика лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре сәнәгый җылылык техникасына, материалларны дымлы җылылык б-н эшкәртү алымнарына, газлы сәнәгать калдыкларын чистартуга, вакуум шартларында җылылык һәм матдә күчерү процессларына карый. С. капилляр-күзәнәкле матдәләрне көчләрәк сублиматик сусызландыру өчен оптималь шартларны билгели, капилляр-күзәнәкле материалларны термик эшкәрткәндә термодиффузия тәэсирен өйрәнә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Александр Невский, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Внешний тепло- и массообмен в процессе конвективной сушки. Минск, 1957; Реодинамика и теплообмен нелинейно вязкопластичных материалов. Минск, 1970 (автордаш); Нестационарный теплообмен. Минск, 1974 (автордаш).

**СМОЛЯКО́В** Борис Петрович (4.7.1936, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1985), проф. (2002). 1961 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук Проблемалы радиоастрономия лаб-ясендә эшли. 1963–96 да РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1985 тән). 1996 дан Казан энергетика ун-ты профессоры.

Хезмәтләре матдәләрнең үзлекләрен импульслы электромагнит һәм тавыш кырларында өйрәнүгә карый. С. югары ешлыклы кыр электр компонентының 2- һәм 3-импульслы тәэсиренә пьезоэлектрик кристалларның когерент гипертавыш җавабын — йөгерек гипертавыш дулкыннарында полярлашкан кайтавазны таба һәм тикшерә (к. *Электроакустик кайтаваз*). Тимер ионнары б-н легирланган һәм лазер импульслары б-н нурландырылган сегнетоэлектрик кристалларда аларның өслеге формалаштырган гипертавыш кайтавазын (дискрет кайтаваз) таба. Тәртипкә салынмаган системадан когерент электромагнитик җавап — пыялаларда микродулкынлы кайтавазны; металл һәм ярымүткәргечләрнең вакуумлы үрнәкләрендә резонанслы циклотрон индукция күренешен ача һәм тикшерә. Полярлашкан гипертавыш кайтавазы сигналлары буенча нәсызыкча пьезоэлектрик эффект һәм нәсызыкча сызылмалылык константаларын билгеләү алымын тәкъдим итә һәм тәҗрибәдә тикшерә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Динамические процессы в диэлектрических стёклах при низких температурах // Успехи физ. наук. 1982. Т. 136 (автордаш); Циклотронная индукция на надповерхностных уровнях твёрдых тел // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1987. Т. 93, вып. 1 (автордаш); Об акустической природе микроволнового эха в силикатных стёклах // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1998. Т. 68, № 11 (автордаш).

**СМОЛЯКО́В** Пётр Трофимович (10.6.1899, Семипалатинск губ., Усть-Каменогорск өязе Терехово а. — 5.5.1952, Казан), геофизик, метеоролог, климатолог, физика-матем. фән. д-ры (1945), проф. (1945). Татарстанда метеорология хезмәтен оештыручыларның (1930) берсе. Семипалатинск пед. ин-тын (1924), Казан ун-тын (1927) тәмамлый, шунда ук эшли, геофизика (1936–48), метеорология һәм климатология кафедралары мөдире (1948–52). Бер үк вакытта Казан ун-тының Метеорология обсерваториясе директоры (1933–34, 1936–52), СССР Гидрометеорология хезмәте Татарстан бүлегенең һава торышын билгеләү хезмәте җитәкчесе (1930–36). Хезмәтләре Татарстан климатына, атм. циркуляциясенә карый. С. планетар циркуляция тикшеренүләрен башлап җибәрә, Җирнең югары атмосферада зур масштаблы моделен төзи. Кояш һәм җил энергиясе режимын һәм аларны Татарстанда файдалану мөмкинлекләрен өйрәнә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Развитие службы погоды в Татарии // Социалист. хоз-во Татарстана. 1933. № 7/8; Весенние и осенние заморозки. К., 1935; К изучению режима и возможности использования солнечной и ветровой энергии в Татарии // Уч. зап. Казан. ун-та. 1936. Т. 96, кн. 1, вып. 4; Климат Татарии. К., 1947.

*Әд.:* П е р е в е д е н ц е в Ю.П. Пётр Трофимович Смоляков. К., 2002.

**СМОЛЯКО́ВА** Лидия Петровна (19.6.1928, Казан — 4.10.2013, шунда ук), тел галиме, филол. фән. д-ры (1980). Казан ун-тын тәмамлый (1953). 1957–58 елларда Барнаул пед. ин-тында. 1959–86 да СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. 1987–2003 тә Казан ун-тының Фәнни китапханәсендә сирәк кульъязмалар бүлегендә. Хезмәтләре рус диалектологиясенә, рус һәм Идел-Чулман буе фин-угор сөйләшләренең үзара бәйләнешләренә карый. «Идел-Чулман буенда яшәүче рус халыклары сөйләшләре атласы»н («Атлас русских народных говоров Волго-Камья», 1972) төзүчеләрнең берсе.

Х е з м.: Формирование фонетической системы русских говоров Волго-Камья. М., 1977.

**СМЫ́КОВ** Виктор Васильевич (17.7.1949, Курск өлкәсенең Тим ш.), геолог, 1985–88 елларда «Ямашнефть» НГДУ башлыгы, икътисад фән. д-ры (2006), ТРның атказ. нефтьчесе (1993), РФнең нефть һәм газ сәнәгате атказ. хезмәткәре (2003). Казан ун-тын (1971), СССР МС каршындагы Халык хуҗалыгы академиясен (1989) тәмамлый. 1971–74 елларда Элиста комплекслы геол.-тикшеренүләр партиясендә (Калмык АССР) геолог булып эшли. 1974 тән (бүленеп) «Татнефть» АҖнең «Ямашнефть» НГДУында: өлкән геолог, район инженер-технология хезмәтендә смена башлыгы, скважиналарны капиталь һәм җир астында ремонтлау буенча өлкән геолог, фәнни-тикшеренү һәм җитештерү эшләре цехы башлыгы, нефть һәм газ чыгару цехы башлыгы. 1979–85 тә партиянең Әлмәт шәһәр ком-тында инструктор, сәнәгать-транспорт бүлеге мөдире. Хезмәтләре углеводород чыганакларын эшкәртү, нефть чыгару экономикасы һәм экологиясе мәсьәләләренә карый. С. нефть ятмаларын эшкәртү, нефть калдыкларын утильләштерү, нефть-газ скважиналары дебитын һәм токымнарның үткәрүчәнлеген бәяләү ысулларын тәкъдим итә. Нефть чыгару һәм башка компанияләрдә корпоратив идарә итүнең Россия һәм чит ил тәҗрибәсен гомумиләштерә. Уйлап табуга 15 патенты бар. «Святой ключ» архит-ра-мәдәният комплексын һәм Казан Мәрьям Ана иконасы хөрмәтенә чиркәү төзүгә зур өлеш кертә (Әлмәт р-нының Аргы Ямаш а.). 2004–09 елларда һәм 2014 тән ТР Дәүләт Советы депутаты. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004). Дуслык, 3 нче дәрәҗә Изге кенәз Даниил Московский, 2 нче дәрәҗә Изгеләштерелгән Сергий Радонежский орденнары, медальләр; ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. Әлмәт р-ны һәм Әлмәт шәһәренең мактаулы гражданы (2003).

Респ-ка «Ел җитәкчесе» иҗтимагый конкурсы лауреаты (2006, 2007).

Х е з м.: Социальная ответственность крупных корпораций: мировой опыт и реалии Татарстана. СПб., 2003; Нелёгкий путь к тяжёлой нефти. К., 2004; Построение и применение постоянно-действующей геолого-технологической модели для длительно разрабатываемого месторождения // Нефтяное хоз-во. 2005. № 3.

**СМЫ́КОВ** Юрий Ильич (6.7.1931, Новосибирск өлкәсенең Куйбышев ш. — 18.3.2015, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1983), проф. (1991), ТАССРның атказ. фән. эшлеклесе (1989). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1955), ТАССР Дәүләт музеенда эшли. 1960–97 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1996 дан ТР ФАнең Тарих ин-ты), Татарстанның тарихи һәм мәдәни ядкәрләре бүлеге мөдире (1989–97). Бер үк вакытта, 1961–2011 дә, Казан ун-тында, 20 йөзгә кадәр Ватан тарихы (2009 дан — Ватан тарихы) каф. профессоры. Хезмәтләре Урта Идел буе авылларының 19 йөзнең 2 нче яртысы чоры тарихына карый. «Татарстан АССР тарихы» («История Татарской АССР», 1968; 3 нче басма, 1980), «Татарстанның эшчеләр сыйныфы (1861–1980)» («Рабочий класс Татарии (1861–1980)», 1981), «Казан тарихы» («История Казани», 1988), «Татарстан Республикасының тарих һәм мәдәният ядкәрләре җыелмасы» («Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан», 1999), «Казан университеты тарихыннан очерклар» («Очерки истории Казанского университета», 2002) һ.б. гомумиләштерүче хезмәтләр әзерләүдә катнаша. Урта Идел а.х. тарихын өйрәнү буенча проблемалы оешма һәм фәнни конференцияләр оештыручыларның берсе. Югары уку йортлары өчен дәреслекләр авторы.

Х е з м.: Сельскохозяйственные машины и орудия в пореформенной деревне Казанской губернии. К., 1958; Крестьянское движение в Казанской губернии в 1878–1879 гг. К., 1959; Крестьяне Среднего Поволжья в борьбе за землю и волю: 60–90-е годы XIX в. К., 1973; Крестьяне Среднего Поволжья в период капитализма: Социально-экон. исслед. М., 1984.

*Әд.:* Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Биобиблиогр. словарь. К., 1999; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**СМЫ́ЛОВКА** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 22 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кама елгасыннан 3 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 95 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Клуб, китапханә. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Абросимовка, Смысловка буларак билгеле. 1860 еллларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе, җил тегермәне, ашлык саклау-сату һәм 2 бакалея кибете эшли. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Сухарево волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 227, 1870 тә — 366, 1897 дә — 563, 1906 да — 608, 1920 дә — 851, 1926 да — 817, 1949 да — 774, 1958 дә — 540, 1970 тә — 492, 1979 да — 353, 1989 да — 107, 2002 дә — 89 кеше.

**СМЫСЛО́В** Валентин Иванович (22.7.1928, Ленинград өлкәсе Невель ш. — 12.3.2004, Мәскәү), дәүләт эшлеклесе. Ленинград корабльләр төзү ин-тын тәмамлый (1951). 1951–69 елларда А.М.Горький исем. Зеленодольск суднолар төзү з-дында: технолог, техник бюро башлыгы (1954 кә кадәр), 1954–55 тә цех башлыгы, 1955–57 дә баш технолог, 1957–62 дә (бүленеп) махсус заказлар буенча әйдәп баручы төзүче, 1962–64 тә баш инженер урынбасары, 1964–66 да баш инженер, 1966 дан — директор. 1969–85 тә СССР Суднолар төзү сәнәгате министрлыгында: «Судозагранпоставка» Бөтенсоюз берләшмәсе башлыгы (1976 га кадәр), 1976–81 дә идарә башлыгы, 1981–84 тә урынбасар, 1984 тән министрның 1 нче урынбасары. 1985–91 дә СССР Дәүләт план ком-ты (Госплан) рәисенең 1 нче урынбасары. Бер үк вакытта, 1985–91 дә, СССР МСның хәрби-сәнәгый комиссиясе рәисенең 1 нче урынбасары. 1992 дән РФ Икътисад министры киңәшчесе. 1986–90 да КПСС ҮК әгъзасы. Хәрби техниканың яңа үрнәкләрен уйлап тапканы өчен СССР Дәүләт бүләгенә лаек була (1979). С. сәнәгать үсешенә һәм дәүләтнең оборона һәм икътисади куәтләрен ныгытуга өлеш кертә, Икътисади ярдәмләшү советы әгъзалары булып торучы илләр б-н хезмәттәшлекне камилләштерүгә булышлык итә. Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Р о г о з и н О.К. Незабываемые имена. СПб., 2004. *Е.Б.Долгов.*

**СНЕГИРЁВ** Вениамин Алексеевич (1841, Түбән Новгород губ. — 16.2.1889, Казан), теолог. Түбән Новгород руханилар семинариясен, Казан руханилар академиясен тәмамлый (1868), шунда ук эшли: логика һәм психол. укытучысы, экстраординар проф. (1872 елдан). Бер үк вакытта, 1877–86 елларда, Казан ун-тында. Казан руханилар цензурасы ком-ты әгъзасы (1877–81). Хезмәтләре гносеология, догматик теология, логика, психология мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Учение о лице Господа Иисуса Христа в трёх первых веках христианства. К., 1870; Вера в сны и снотолкование. К., 1874; Психологические сочинения Аристотеля. К., 1885; Логика. Хар., 1901.

*Әд.:* Н е с м е л о в В. Памяти Вениамина Алексеевича Снегирёва // Православный собеседник. 1889. Май.

**СО́БОЛЕВ** Иван Николаевич (1813, Рыбинск ш. — 16.3.1878, С.-Петербург), Казан сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе, шәһәрнең нәселдән күчмә мактаулы гражданы. Ашлык б-н сәүдә итә, төзелеш эшләрен оештыра. *Сәүдәгәрләр биржасын* оештыручыларның берсе, 1874 елда аны урнаштыру өчен Проломная урамында бина төзеп шәһәргә бүләк итә. 1868–73 тә Казан биржа ком-тының беренче рәисе. С. башлангычында 1869 дан «*Казанский биржевой листок*» г-тасы чыга башлый, Казан реаль уч-щесе ачыла (1875) һәм уч-ще өчен бина салына; С. истәлегенә аның исемендәге



Н.А. Соболев.



Н.Л. Соболев.

2 стипендия булдырыла. 1873 тән Үзара кредитлашу җәмгыятенең, 1875 тән Дәүләт банкының Казан бүлеге хисап ком-ты әгъзасы. Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-ты чиркәве старостасы, аның бинасын төзекләндерүгә акча бүлеп бирә. Казан аша тимер юл төзүне кайгырту «депутациясе»нә сайлана.

*Л.М.Свердлова.*

**СО́БОЛЕВ** Николай Алексеевич (5.5.1919, Сембер губ., Буа өязе Иске Борындык а. — 31.3.2007, Яшел Үзән ш.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Соц. Хезмәт Герое (1971). Казан партия мәктәбен тәмамлый (1950). 1935–45 елларда Будённый р-нының Әлши авылында элемтә агентлыгы мөдире, Буа р-нының Иске Борындык авылында элемтә бүлеге башлыгы булып эшли. 1945–50 дә ВКП(б)ның Олы Тархан район ком-ты секретаре ярдәмчесе, 1950–55 тә КПССның Әлки, Куйбышев район ком-тларының оештыру бүлеге мөдире. 1955–58 дә Куйбышев р-нының «Красный луч» к-зы рәисе, 1958–60 та район башкарма ком-ты рәисе урынбасары, 1960–72 дә Әлки р-нының «Россия» к-зы рәисе. С. җитәкче булганда, «Россия» к-зында ит җитештерү — 28,1% ка, сөт — 75,6% ка, бөртекле культураларның уңышы — 2,2 тапкыр, еллык савым һәр сыердан уртача 12,5% ка арта. Соц. Хезмәт Герое исеме 8 нче бишьеллык (1966–70) нәтиҗәләре буенча а.х. продукциясен җитештерүдәге югары күрсәткечләре өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Колхозчыларның 3 нче Бөтенсоюз съезды делегаты (1969). Ленин ордены, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*

**СО́БОЛЕВ** Николай Леонтьевич (19.12.1904, Вильно ш., хәзер Литва Респ-касының Вильнюс ш. — 2.2.1957, Зеленодольск ш.), Сов. Союзы Герое (17.10.1943), гв. сержанты. Казанда фабрика-кухня директоры булып эшли. 1926–29 елларда һәм 1942 дән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең мартыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 57 нче танк бригадасының (60 нчы армиянең 7 нче механикалаштырылган корпусы) танкка ата торган мылтык взводы командиры. Үзәк фронт гаскәрләре составында Сулъяк яр Украинаны азат итүдә катнаша (1943). Домантово авылы (Украина ССР, Киев өлкәсенең Чернобыль р-ны) янында Днепрны кичкәндә батырлык күрсәтә: 1943 нең 25 сентябрендә, сафтан чыккан рота командирын алыштырып, ротаның уңъяк ярга кичүен оештыра;

плацдармны киңәйтү өчен барган бәрелештә дошманның 2 танкын юк итә, контрһөҗүмнәрне кире кайтаруда катнаша. Авыру сәбәпле, 1943 тә демобилизацияләнә. Яр буе Морквашы авылында (Югары Ослан р-ны) пионерлагерь директоры булып эшли, 1951 дә Васильево посёлогына (Зеленодольск р-ны) күчә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СОБОЛЕ́ВСКИЙ** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 45 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зөя елгасы буенда. 2010 елда 140 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 92%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Тихвин Богородица чиркәве. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Халкы башта Зөя Троица монастырена карый, 1763 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу һәм йон тетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.да иске дин тарафдарлары гыйбадәтханәсе, чиркәү-приход мәктәбе (1897 дә ачыла), телефон, су тегермәне, салат һәм кирпеч з-длары, йон тетү йорты, 2 сыраханә, чәйханә, 1 казна шәраб һәм 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1531 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Келәнче волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1772 дә — 103 ир-ат; 1859 да — 592, 1897 дә — 1055, 1908 дә — 1188, 1920 дә — 1244, 1926 да — 1266, 1938 дә — 996, 1949 да — 594, 1958 дә — 312, 1970 тә — 329, 1979 да — 225, 1989 да — 197, 2002 дә — 186 кеше.

**СОБОЛЬЩИКО́В-САМА́РИН** Николай Иванович (28.3.1868, С.-Петербург — 20.7.1945, Горький ш), драма актёры, режиссёр, антрепренёр, РСФСРның халык артисты (1934). Сәхнә эшчәнлеген 1884 елда башлап җибәрә. 1892–99 да Түбән Новгород театры актёры һәм режиссёры. 1899–1901 дә — Әстерхан, Баку шәһәрләре театрлары, 1901–09 да Казан һәм Саратов театрлары антрепренёры, аларда, чиратлашып, опера һәм балет труппалары эшли. Казан театры сәхнәсендә, беренчеләрдән булып, М.Горькийның «Фома Гордеев» (1902) повесте инсценировкасын, «Мещаннар» («Мещане», 1902), «Тормыш төбендә» («На дне», 1903), «Дача тотучылар» («Дачники», 1905), «Кояш балалары» («Дети солнца», 1905), «Варварлар» («Варвары», 1906) пьесаларын, «Саллларда» («На плотах», 1905), «Өчәү» («Трое», 1906), «Мальва» (1908) хикәяләрен сәхнәләштерә. Күп тапкырлар Е.Н.Чириков, С.А.Найдёнов, Е.Ю.Геркен, Н.Ф.Юшков кебек Казан драматурглары пьесаларына да, ш.у. Л.Н.Толстой, Л.Н.Андреев, А.П.Чехов әсәрләренә дә мөрәҗәгать итә. Беренчеләрдән булып, Казанда А.П.Чеховның «Чия бакчасы» («Вишнёвый сад», 1904) әсәре буенча спектакль куя. К.С.Станиславский ысулларын дәвам итә; актёрлар б-н эшләгәндә, С.-С. алардан иң элек геройларның эчке дөньяларына тирәнтен үтеп керүләрен таләп итә, социаль һәм рухи каршылыкларны ачып, сәхнә конфликтын төгәл төзүгә, башкару бердәмлегенә ирешә. Актёр буларак, Казанда М.Горький әсәрләре буенча куелган спек-



Н.И. Собольщиков-Самарин.

такльләрдә Фома («Фома Гордеев»), Бессеменов («Мещаннар»), Актёр («Тормыш төбендә»), Илья («Өчәү»), Василий («Мальва») рольләрен башкара, аларда геройларның гыйсъянчы табигатен һәм романтик рух күтәренкелеген ышандырырлык итеп гәүдәләндерә. С.-С. ш.у. Андрей Прозоров һәм Лопахин («Өч сеңел» һәм «Чия бакчасы», А.П.Чехов), Иван Мироныч (шул исем. әсәр буенча, Е.Н.Чириков), Лир («Король Лир», У.Шекспир), Бранд (шул исем. әсәр буенча, Г.Ибсен) рольләрен дә башкара. *Казанда опера сезоннарының* иң югары күтәрелеше С.-С. исеме б-н бәйле, ул гастрольләргә В.Ф.Комиссаржевская, М.В.Дальский, М.Г.Савина, К.А.Варламов, П.П.Гайдебуров кебек күренекле артистларны чакыра. С.-С. эшчәнлеге Казан театр тарихында тирән эз калдыра. Аннан соңгы елларда Ростов-Дон, Одесса шәһәрләре театрларында эшли, 1924 тән Горький драма театры актёры, режиссёры һәм сәнгать җитәкчесе.

Х е з м.: Записки. Г., 1940.

*Әд.:* Б о г о л ю б о в Н.Н. Полвека на оперной сцене. М., 1957; Б л а г о в Ю.А. Казанская антреприза Собольщикова-Самарина. К., 2004; Театральная энциклопедия. М., 1965. Т. 4.

*Ю.А.Благов.*

**«СОВЕ́Т ӘДӘБИЯТЫ́»**, журнал; к. «*Казан утлары*».

**СОВЕ́Т ВЛАСТЕ́ ӨЧЕ́Н КӨРӘШТӘ́ ҺӘЛА́К БУЛГАННА́Р МОНУМЕ́НТ-ҺӘЙКӘЛЕ́**, Казанда. Совет чорында куелган һәйкәлләрнең иң әһәмиятлеләреннән берсе. Окт. рев-циясе, Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышы елларында илнең иреге һәм мөстәкыйльлеге өчен гомерләрен биргән көрәшчеләр истәлегенә, Окт. рев-циясенең 50 еллыгы уңаеннан куела. М.Горький исем. Үзәк мәдәният һәм ял паркы алдындагы төп керү мәйданында урнашкан. 1967 елның 6 ноябрендә ачыла. Авторлары: скульп. В.М.Маликов, архитекторлар Г.М.Пичуев һәм А.А.Спориус. Һәйкәл җирдән 1 *м* күтәренкерәк, 28×56 *м* үлчәмле гранит мәйданчыктагы 39 *м* биеклектәге стела-обелиск һәм монументаль-скульптур «Васыять» («Завет») фигурасыннан тора. Шомартылган титан стела совет хакимиятенең уңышларын, казанышларын чагылдыра. Скульптура үлем ярасы алган, соңгы көчен җыеп җирдән күтәрелүче көрәшченең гомумиләштерелгән символик образын сурәтли. Сул кулы б-н постаментка таянган, уң кулын алга, югарыга сузган, ул гомерләрен корбан иткән миллионнарча үткән буынның эшен дәвам итәргә киләчәк буыннарны чакыра кебек. Идея-сәнгати ният скульптураның образлылыгын һәм пластик төзелешен билгели, аның үзенчәлеге — форма төгәллеге, тәэсирлелек. Кырлы яссылыклар һәм детальләр совет власте өчен көрәшүчеләрнең ныклыгы һәм җиңелмәслеге идеясен чагылдыра. Билгеле бер өс киеме монументны аерым бер чорга бәйләмәсен өчен, сын ялангач сурәтләнә. Һәйкәл көрәшченең җиңелмәс рухын, көчле ихтыярын, Ватан өчен үзен корбан итәргә әзерлеген гәүдәләндерә.

К. Иллюстрациясе В.М.*Маликов* мәкаләсендә.

*А.И.Новицкий.*

**«СОВЕ́Т ВЛАСТЕНА́ КАРШЫ́ ОЕШКА́Н ТӨРКЕ́М» ЭШЕ́**, 1942–43 елларда ТАССРның НКВД органнары тарафыннан оештырыла. Бу эш буенча немец милләтеннән булган 5 кешене хөкем итәләр. Алар «Волжлаг» терр-ясендә (Зөя каласы) совет хакимиятенә каршы фашистик агитация уздыруда, коткы таратуда, фашистлар Германиясе б-н сугышта җиңелүне пропагандалауда, дошманнар ягына күчәргә өндәүдә гаепләнәләр. Мәхкәмә утырышы 1943 елның 25 мартында Казанда уза. Д.Д.Вальтер, Г.Х.Вольф, Ф.Ф.Круг, К.И.Штангка карата 10 елга төрмәгә ябылу һәм 5 елга хокукларыннан мәхрүм ителү, Я.Я.Шумахерга карата 8 елга төрмәгә ябылу һәм 5 елга хокукыннан мәхрүм ителү хөкеме чыгарыла. 1989 ның 7 июнендә РСФСР Югары мәхкәмәсе Президиумы хөкем карарын кире кага һәм, җинаятьчелек составы булмау сәбәпле, бу эшне туктата; барысы да аклана.

**«СОВЕ́Т МӘКТӘБЕ́»**, журнал; к. «*Мәгариф*».

**СОВЕ́Т СОЦИАЛИ́СТИК РЕСПУ́БЛИКАЛАР СОЮЗЫ́** (СССР, Советлар Союзы), элекке *Россия империясе* биләмәсенең зур өлешендә барлыкка килгән һәм 1922–91 елларда яшәгән дәүләт. СССР төзелү турындагы Килешү нигезендә (1922) аның составына Белоруссия (Белоруссия ССР), РСФСР, Кавказ арты Совет Социалистик Респ-калар Федерациясе, 1936 дан — союздаш респ-калар: Әзәрбайҗан (Әзәрбайҗан ССР), Әрмәнстан (Әрмәнстан ССР), Грузия (Грузия ССР), Украина (Украина ССР); 1925 тән — Үзбәкстан (Үзбәкстан ССР) һәм Төрекмәнстан (Төрекмәнстан ССР), 1929 дан — Таҗикстан (Таҗикстан ССР), 1936 дан — Казакъстан (Казакъстан ССР) һәм Кыргызстан (Кыргызстан ССР), 1940 тан Молдавия (Молдавия ССР), Латвия (Латвия ССР), Литва (Литва ССР) һәм Эстония (Эстония ССР), ш.у. 1940–56 да Карел-Фин ССР керә. 1991 нең декабрендә Белоруссия, Россия һәм Украина җитәкчеләре СССРның таркалуын игълан итәләр һәм Бәйсез Дәүләтләр Берләлеге (БДБ) оештырылу турындагы Килешүгә кул куялар.

Татарстан СССР составына РСФСРның автономияле респ-касы сыйфатында керә. 1917 елгы Февр. һәм Окт. рев-цияләре нәтиҗәсендә Россия империясендә яшәгән рус булмаган халыкларның милли азатлык хә-

рәкәтләре активлашкан чорда татар халкы, үзенең милли дәүләтчелеген торгызу — *Идел-Урал Штаты*, большевиклар хакимияте ныгыган шартларда *Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасы* төзү өчен, берничә тапкыр омтылыш ясый. Мондый юнәлештә респ-ка СССР төзелгән вакытта союздаш респ-ка статусын дәгъвалый алган булыр иде, әмма бу проектлар тормышка ашмый кала. 1920 нең 27 маенда БҮБК һәм РСФСР ХКСның РСФСР составындагы «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы турында»гы Декретына кул куела. 1920 елларның 1 нче яртысында СССРның милли дәүләт төзелеше нигезләре һәм принципиаль яңа дәүләт берләшмәсе буларак оешуы хакында фикер алышулар барышында Татарстан вәкилләре милләтләр һәм халыклар арасында тигез хокуклылыкны, аларның тарихи һәм мәдәни традицияләрен исәпкә алуны яклап чыгалар. Советларның 10 нчы Бөтенроссия съездында (1922 нең декабре) И.В.Сталинның РСФСР автономияле респ-каларының тигез хокуксызлыгын күздә тоткан сов. респ-каларын берләштерү турындагы чыгышыннан соң РКП(б) фракциясе утырышында РСФСРның Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты коллегиясе әгъзасы М.Х.*Солтангалиев* РСФСР автономияле респ-каларының һәм Кавказ арты Совет Социалистик Респ-калар Федерациясенең турыдан-туры СССР составына керүләре мөһимлеге турында ачыктан-ачык әйтә, «милләтләрне газиз һәм үги балаларга бүлү»нең киләчәкне алдан күреп эш итә белмәү билгесе булуына басым ясый. Автономияле респ-каларга СССР субъектлары булу хокуклары бирү турында башка делегатлар да әйтәләр, әмма Сталин басымы б-н тәкъдимнәр кабул ителми кала. Солтангалиев СССРның, җирле милләтчелеккә китерүче бөек державачылык шовинизмына нигезләнгән дәүләт буларак, котылгысыз рәвештә таркалачагы хакында кисәтә. 1920 елларның 2 нче яртысыннан, СССРда тоталитар система көчәю б-н, ил җитәкчелегенең милли сәясәтендә рус булмаган халыкларның милли үзенчәлекләрен чикләүне күздә тоткан җитди үзгәрешләр барлыкка килә, бу исә аларның телләре һәм мәдәниятләре үсешенә зур зыян сала. Совет хакимияте елларында ике тапкыр алфавит үзгәрүне (1927, 1939) кичерү дә татар халкының хәлен мөшкелләндерә. Сугыштан соңгы елларда СССРда татар уку йортларын, вакытлы матбугат басмаларын, мәдәният учреждениеләрен планлы рәвештә ябу, ш.у. милли мәктәпләрдә рус телендә укытуга күчү процесслары бара (1958 дә Казанда нибары 3 татар һәм 17 катнаш мәктәп эшли). Сталин репрессияләре чорында күренекле дәүләт, мәдәният, фән эшлеклеләрен репрессияләү һәм физик юктан юк итү милли дәүләтчелек һәм мәдәният үсешен тоткарлый. «Хрущёв җепшеклеге» елларында илнең сәяси тормышы билгеле бер дәрәҗәдә либеральләшү татар җәмәгатьчелегендә милли сәясәттә йомшаруга өметләр уята. КПССның 20 нче съездына кадәр үк инде респ-каның иҗат эшлеклеләре төркеме КПСС ҮК-на татар мәдәниятен торгызу мәсьәләләре б-н беррәттән Татарстанга союздаш респ-ка статусы бирү мәсьәләсен дә күтәреп чыккан хат җибәрә. 20 нче съезддан соң татар зыялыларының бу мәсьәләләрне яктырткан чыгышлары тагын да активлаша. Әмма СССР җитәкчелеге дә, респ-ка хакимиятләре дә аларның тырышлыгын хупламый. ТАССРда милли мәсьәләнең, тулаем алганда, СССРдагы кебек үк хәл ителгән булуы рәсми рәвештә раслана. Татар зыялылары мохитендә респ-ка статусын күтәрү хакындагы мәсьәлә СССР (1977), РСФСР һәм ТАССР (1978) Конституцияләрен кабул итү б-н бәйле рәвештә яңадан калкып чыга. Респ-ка җитәкчеләре милли интеллигенциянең игътибар таләп иткән этносәяси мәсьәләләрне хәл итәргә омтылуларына әһәмият бирмәү ягында булалар. СССРның иҗтимагый-сәяси һәм икътисади тормышында торгынлык хөкем сөргән чорда Татарстан җәмәгатьчелегенең сәяси актив катлаулары арасында илнең милли-дәүләти төзелеш формасының, респ-ка статусының үсеш потенциалы юкка чыгу, аларның үзгәртеп коруга мохтаҗлык кичергән система элементлары гына булып калулары турында ныклы караш урнаша. 1980 елларның 2 нче яртысында совет җәмгыятен демократияләштерү һәм Россия регионнарында милли хәрәкәт үсеше шартларында Татарстанда респ-ка статусы үзгәрү хакындагы мәсьәлә яңадан күтәрелә. 1990 да Татарстан Совет Социалистик Респ-касының дәүләт суверенлыгы турында декларациясе кабул ителә, анда Татарстан статусының союздаш респ-калар дәрәҗәсенә күтәрелүе игълан ителә. СССРның тиз арада таркалуы әлеге мәсьәләнең көн кадагыннан юкка чыгуына китерә, *Татарстан Республикасы* исә СССРның тулы хокуклы дәвамчысы булган *Россия Федерациясе* составында чираттагы үсеш чорына керә.

Чыг.: Образование и государственно-правовое положение Татарской АССР: Сб. док. и материалов. К., 1960; Образование Татарской АССР: Сб. док. и материалов. К., 1963.

*Әд.:* Х а ф и з о в Ш.Ш. Образование Татарской АССР. К., 1960; История национальной государственности в Татарии. К., 1982; И с х а к о в Д.М. Проблемы становления и трансформации татарской нации. К., 1997; Т а г и р о в И.Р. История государственности Татарстана. XX век. К., 2005.

*Л.М.Айнетдинова.*

**«СОВЕ́Т СУГЫШЧЫСЫ́»**, фронт газетасы. 3 нче Украина фронтының сәяси идарәсе органы. 1943 елның маеннан 1946 ның февраленә кадәр татар телендә нәшер ителә, барысы 385 саны чыга. Мөхәррире — М.Г.Максуд. Газетада А.Әсәдуллин, Г.Әхмәтшин, В.Вәлиев, М.Кәрим эшли. Редакциягә командировкага Х.Хәйри җибәрелә. Штаттан тыш хәбәрчеләре капитан М.Бурнашев, рядовой Б.Вәлиев, сержант Х.Галиев була.

*Әд.:* М а к с у д М.Г. Дорогие минуты. К., 1963.

**«СОВЕ́Т ТАТАРСТАНЫ́»**, газета; к. «*Ватаным Татарстан*».

**«СОВЕ́Т ТАТАРСТАНЫ́»**, бомбардировщиклар авиаэскадрильясе. Бөек Ватан сугышы елларында респ-када, Кызыл Армиягә хәрби техника (бронепоездлар, танклар һ.б.) төзү өчен, акча җыю эше башланып китә. 1943 елның башында, «С.Т.» авиаэскадрильясен төзү өчен, акча җыя башлыйлар. Актаныш р-нында — 5 млн. 820 мең, Әтнә р-нында — 3 млн. 758 мең, Арча р-нында — 3 млн. 458 мең, Кызыл Юл р-нында — 3 млн. 883 мең, Балтач р-нында — 3 млн. 359 мең, Апас р-нында 3 млн. 220 мең сум акча җыела. Эшчеләрдән, инженер-техник хезмәткәрләрдән һәм Казанда хезмәт итүчеләрдән авиаэскадрилья төзелеше фондына 22 млн. сум акча кертелә. 1943 нең мартына 100 млн. сумнан күбрәк акча җыела. 1943 нең 1 маенда Казан аэродромында фюзеляжларына «С.Т.» дип язылган 102 данә Пе-2 самолёты респ-ка вәкилләре (эшчеләр, колхозчылар, ТАССР ЮС Президиумы рәисе Г.А.Динмөхәммәтов, ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты секретаре С.Ш.Гафаров, хөкүмәт әгъзалары) тарафыннан тантаналы рәвештә *Урта Дон бомбардировщиклар авиация дивизиясенә* тапшырыла. Ул самолётлар Курск дугасы сугышларында катнаша.

*Әд.:* Г и л ь м а н о в З.И. Татарская АССР в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг. К., 1977.

**СОВЕТЛА́Р СОЮЗЫ́**, к. *Совет Социалистик Республикалар Союзы.*

**СОВЕТЛА́Р СОЮЗЫ́ ГЕРОЕ́**, 1934–91 елларда СССРда иң югары дәрәҗәле мактаулы исем, дәүләт һәм халык алдында аерым шәхес яки коллектив тарафыннан күрсәтелгән каһарманлык, батырлык өчен бирелә. СССР ҮБКның 1934 ел 16 апрель карары нигезендә булдырыла. 1936 ның 29 июнендә расланган Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, бу исем СССР ЮС Президиумы тарафыннан бирелә. Геройларга — СССР ҮБКның махсус грамотасы, ә 1936 дан СССРның иң югары бүләге — Ленин ордены тапшырыла. С.С.Г. исеменә лаек булган гражданнарны махсус бүләкләү максатыннан СССР ЮС Президиумының 1939 ел 1 август карары нигезендә «Алтын Йолдыз» медале булдырыла. Шул вакыттан алып, С.С.Г.на СССРның иң югары бүләге — Ленин ордены, махсус бүләк — «Алтын йолдыз» медале һәм СССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы тапшырыла, кешегә С.С.Г. исеме кабаттан бирелгән очракта, ул «Алтын Йолдыз» медале һәм грамота б-н бүләкләнә. Батырлыкларын билгеләү максатыннан ике тапкыр С.С.Г. булган кешенең — туган җирендә, өч тапкыр С.С.Г. булган кешенең — Мәскәүдә бронзадан бюсты куела. Татарстанда яшәүчеләр арасында С.С.Г. исеменә 187 кеше лаек була, аларның 63 е — татар. СССРның башка респ-калары, край һәм өлкәләреннән булган татарлар арасында якынча 160 кеше С.С.Г. исеменә лаек була. Татарстанда туып үскән, Бөек Ватан



Советлар Союзы Героеның «Алтын Йолдыз» медале.

сугышы елларында авиация полкы штурманы булган Н.Г.Столяров С.С.Г. исеменә ике тапкыр (1944 тә һәм 1945 тә) лаек була. Алфавит буенча исемлекне 1 нче кушымтада кара.

Чыг.: Собрание законов и распоряжений Рабоче-Крестьянского Правительства СССР. М., 1934; Сборник законов СССР и Указов Президиума ВС СССР, 1938–1961. М., 1961.

*Әд.:* Славные сыны Башкирии: В 5 кн. Уфа, 1965–85; Р а к и п о в Ш.З. Хранить вечно. К., 1980; Герои Советского Союза — наши земляки: В 3 кн. К., 1982–85; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь: В 2 т. М., 1987–88; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СОВЕТЛА́Р СОЮЗЫ́ КОММУНИСТЛА́Р ПА́РТИЯСЕ** (КПСС), 1898–1991 еллардагы сәяси партия. 1898 елның мартында Минскида Россия с.-д. оешмаларының 1 нче съездында Россия с.-д. эшчеләр партиясе (РСДРП) буларак оеша. Партиянең ҮКы сайлана һәм максатлары билгеләнгән манифесты эшләнә. Шулай да ул чакта Россиянең барлык с.-д. оешмалары да тулысынча берләшми. Россиянең марксистик оешмалары бердәмлеген булдыру максатыннан В.И.*Ленин* инициативасы б-н легаль булмаган гомумроссия «Искра» сәяси г-тасы нәшер ителә башлый, аның 1 нче саны 1900 елның 11 декабрендә Лейпциг шәһәрендә чыга. «Искра» редакциясе (В.И.Ленин, Ю.О.Мартов, А.Н.Потресов, Г.В.Плеханов, П.Б.Аксельрод, В.И.Засулич һ.б.) партиянең программа проектын эшли һәм 1903 нең июль–августына РСДРПның 2 нче съезды чакырылышын билгели (Брюссель, Лондон). Анда программа-минимум (буржуаз-демократик рев-ция этабында пролетариатның якын арада хәл итәргә тиешле бурычлары: самодержавиене бәреп төшерү, барлык крепостнойлык калдыкларын да юк итү, демократик респ-ка урнаштыру, 8 сәгатьлек эш көне кертү, барлык милләтләрнең дә тигез хокуклылыгын һәм аларның үзбилгеләнү хокукларын булдыру, иҗтимагый-сәяси тормышны демократлаштыру) һәм программа-максимум (соц. рев-ция этабында партиянең бурычлары: пролетариат диктатурасы урнаштыру һәм социализм төзү) раслана. Съездда партиянең оешу принципларына карата көчле бәхәс куба. В.И.Ленин һәм аның тарафдарлары фикеренчә, партия проф. булырга, оешкан бербөтен буларак чыгыш ясарга, барлык үз әгъзаларының кылган гамәлләрендә бердәмлек тәэмин итәргә һәм югары дисциплина булдырырга тиеш. Ю.О.Мартов һәм аның тарафдарлары теләгән бар кешене дә партиягә алырга һәм аның катгый тәртипләре б-н беркемне дә кысмаска тәкъдим ясый. Тавыш бирү нәтиҗәсендә оешманың Уставында нәкъ шул нигез чагылыш ала. Партиянең үзәк органнарын сайлаган вакытта Ленин тарафдарлары күпчелек урынны били, шуңа күрә алар — *большевиклар*, ә аларга каршылар *меньшевиклар* дип йөртелә башлый. Формаль яктан РСДРП бердәм сәяси оешма буларак сакланып калса да, асылда исә 2 нче съездан соң Россиянең сәяси аренасында 2 мөстәкыйль оешма — большевиклар һәм меньшевиклар барлыкка килә, алар арасында килештергесез идеологик көрәш бара. 1905 ел башына РСДРПда 32 большевиклар ком-ты һәм 35 төркем исәпләнә. 1905 нең 12 апреленнән алып 27 апреленә кадәр Лондонда РСДРПның 2 нче съезды уздырыла, анда бары тик большевиклар гына була. Меньшевиклар анда катнашудан баш тарталар һәм Женевада үзләренең бәйсез конференциясен уздыралар. Шул рәвешчә РСДРПның ике фракциягә бүленүе раслана. 1905–1907 еллардагы Рев-ция шартларында большевикларның стратегиясе катгый була: рев-ция буржуаз-демократик характерда булуга карамастан, аның төп этәргеч көче пролетариат санала, кораллы күтәрелеш оештыру, хөкүмәтне бәреп төшерү, демократик респ-ка урнаштыру, аннан соң буржуаз-демократик рев-циянең кичектергесез рәвештә соц. рев-циягә кадәр үсеше өчен көрәшне дәвам итү күздә тотыла. РСДРПның үзәк органнарындагы фикер каршылыгы урыннарда партиянең бердәмлеген какшата, аның гади әгъзаларын аптырашта калдыра. 1906 ның апрелендә Стокгольмда партиянең 4 нче берләштерү съезды уза. Анда сан ягыннан меньшевиклар күбрәк була. Партия җитәкчеләре арасында бердәмлеккә ирешелми. Берләшү формаль гына булып кала. 1912 нең гыйнварында РСДРПның 6 нчы Бөтенроссия Прага конференциясе уза, анда большевиклар меньшевикларны партиядән чыгаралар, В.И.Ленин җитәкчелегендәге большевиклар ҮКын сайлыйлар, Россиядә партия эше б-н җитәкчелек итү өчен, большевиклар РСДРП ҮКның Рус бюросы төзелә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң, большевиклар оешмалары РСДРП(б) исемен алгач һәм хакимиятне кулга төшерү өчен көрәшкә күтәрелгәч, РСДРП ахыргача таркала. Окт. рев-циясе нәтиҗәсендә большевиклар хакимияткә килә һәм беренче совет хакимияте органнарын оештыра. Баштарак аларга меньшевиклар да, *сул эсерлар* да керә. Партиянең 7 нче съездында (Петроград, 1918 нең марты) аның яңа исеме раслана: Россия коммунистлар (большевиклар) партиясе — РКП(б). Партиянең 8 нче съездында (Мәскәү, 1919 ның марты) социализм төзү бурычларын билгеләүче яңа Программа кабул ителә. 1920 еллар башында партия җитәкчелеге илдәге барлык башка сәяси партияләрнең эшчәнлеген тыя, шул рәвешчә большевиклар партиясе диктатурасын урнаштыра. 1925 тән партия — Бөтенсоюз коммунистлар (большевиклар) партиясе — ВКП(б), 1952 дән КПСС дип (партиянең 19 нчы съезды) атала башлый. Хакимиятнең үзәктәге һәм урыннардагы барлык этәргеч көчләрен берләштергән партия бердәнбер оешмага әверелә, ә коммунистлар идеологиясе СССРда яшәгән халыклар тормышына һәм эшчәнлегенә караган барлык өлкәләрне дә колачлый. Партия съездларында СССРның барлык эчке һәм тышкы сәясәте билгеләнә. Мәс., 10 нчы съездда (1921 нең 8–16 марты) *«хәрби коммунизм»* сәясәтеннән *яңа икътисади сәясәткә* күчү игълан ителә; 14 нче съездда (1925 нең 18–31 дек.) тизләтелгән *индустрияләштерүгә* юнәлеш алына; 22 нче съездда (1961) партиянең илнең «коммунизмның киң колачлы төзелеше» чорына керүен игълан иткән 3 нче программасы гамәлгә кертелә; 1980 еллар уртасында КПССның ген. секретаре М.С.Горбачёв илдә үзгәртеп кору курсын игълан итә.




Чистай партия оешмасының әгъзалык билеты тышлыгы. 1918.



Мөселман коммунистның әгъзалык билеты. 1920.

1880–90 елларда Казан губернасында Н.Э.*Бауман*, К.К.*Газенбуш*, А.С.Кулеша, Н.А.Семашко, А.М.*Стопани*, Е.П.Табейкин, Н.Е.*Федосеев* һ.б. җитәкчелегендә с.-д. (марксистик) түгәрәкләре эшли. 1897 дә беренче с.-д. төркеме оеша. Казан с.-д.ы эшчәнлеге 1902 нең ахырында РСДРПның Казан ком-ты төзелүгә җирлек тудыра, аның б-н Ленин тарафдары А.П.Бржезовский җитәкчелек итә. 1917 нең мартына кадәр ком-т яшерен рәвештә эшли, күп тапкыр кулга алына һәм эзәрлекләнә, әмма яңадан торгызыла һәм актив эшчәнлек алып бара. Аның тарафыннан рус һәм татар телләрендә прокламацияләр басыла. Партиянең 2 нче съездыннан соң Казан ком-ты (В.В.*Адоратский*, Л.А.Фотиева, А.С.Кулеша, Н.Е.Фирсов, Н.К.Морозов һ.б.) большевиклар позициясен хуплый. Ком-тның төп эшчәнлеге яшерен әдәбият таратуга, эшчеләр, шәкертләр, солдатлар арасында агитация эшләре алып баруга юнәлдерелгән була. 1904 нең ноябрендә беренче яшерен басмаханә булдырыла. 1905 ел башында большевикларның Казан ком-тындагы позицияләре шактый йомшара төшә. Партиядә төрле фикер каршылыклары хөкем сөргән вакытта ул килешү халәтен кабул итә. 1905 нең февралендә Казанга килгән большевик Я.М.Свердлов инициативасы б-н яңа ком-т төзелә (И.А.*Саммер*, С.А.*Лозовский*, В.В.Адоратский, Х.М.*Ямашев* һ.б.). 3 нче съездан соң Казан ком-ты икегә — большевикларга һәм меньшевикларга (РСДРПның Казан төркеме) бүленә. 1905 нең августында Казан ком-ты ныгытыла һәм киңәйтелә (10 кеше), аның каршында крәстияннәр (округ), татар-

лар арасында эш алып бару (Х.М.Ямашев җитәкчелегендә), хәрбиләр төркемнәре оеша. 1905 ел ахырына Казан большевиклар оешмасында 400 дән артык кеше исәпләнә. 1905–07 еллардагы Рев-ция чорында большевиклар инициативасы б-н төбәктә күп кенә забастовкалар һәм демонстрацияләр уздырыла. 1912 дә, чираттагы тар-мар ителүдән соң, яңадан «Казан большевиклар-ленинчылар төркеме» оеша, ком-т (М.П.Жаков, М.М.Золина-Вилонова, В.Александров), секретариат, техник, финанс һәм пропаганда төркемнәре барлыкка килә. Хәтта ком-т ябылганнан соң да, большевиклар Казанның эре пр-тиеләрендә оешкан завод ячейкаларында һәм түгәрәкләрендә актив эшләүләрен дәвам итәләр. 1916 ел ахырында, ком-т булмаган дәвердә, ячейка һәм түгәрәкләрнең эшчәнлеген координацияләү өчен, «Эшче революционерлар ком-ты» төзелә, ул эсерлар б-н берлектә гектографта басылган «Клич» ж-лын чыгара. 1917 нең мартында Казанга партия ҮК тарафыннан җибәрелгән В.А.*Тихомирнов* инициативасы б-н Казан ком-ты яшерен рәвештә кабат торгызыла. Аңа 16 кеше керә: В.А.Тихомирнов (рәис), Г.Ш.*Олькеницкий*, И.Н.*Волков*, И.Я.*Гладилов*, А.П.*Комлев* һ.б. Апрель башында Казанда 5 район оешмасы барлыкка килә. Казан партия оешмасы Уставы 1 нче гомумшәһәр большевиклар җыелышында кабул ителә. Май аенда оешмада якынча 400 кеше исәпләнә. 1917 нең язында анда Казан губернасының башка шәһәрләрендә дә — Чистай (И.Гуськов, В.Бажанов, Г.Корнилов һ.б.), Спас (Г.С.*Гордеев*), Мамадыш (А.Давыдов), Козьмодемьянскида (М.Красильников) большевиклар ком-тлары оеша. Казан большевиклары б-н М.М.*Вахитов* тарафыннан оештырылган Мөселман социалистлар ком-ты элемтәдә тора. Тихомирнов киткәннән соң, Казан ком-ты б-н Г.Ш.Олькеницкий җитәкчелек итә. 1917 нең җәендә һәм көзендә, эсерлар һәм меньшевиклар б-н Эшче һәм солдат депутатлары советлары өчен кискен көрәш барышында, большевиклар җиңү яулыйлар һәм Советларда урыннарның күпчелеген билиләр, Казан шәһәр думасына сайлауларда алар 22 урын алуга ирешәләр. Сентябрьдә-октябрь башында большевикларның 1 нче гомумгуберна конференциясе булып уза: анда РСДРП(б) ком-ты сайлана (И.Н.Волков, Г.Ш.Олькеницкий, А.Бочков, К.Я.*Грасис*, А.И.*Карпов* һ.б.), хәрби оешма төзелә (рәисе Н.Е.*Ершов*, урынбасары Н.Я.*Ежов*). Большевиклар инициативасы б-н заводларда актив рәвештә кызылгвардиячеләр отрядлары оеша: дары заводында гына да мондый отрядка 400 гә якын кеше керә. Казанда кораллы күтәрелеш башланган вакытта 3 мең кызылгвардияче була. 1917 нең октябрендә РСДРП(б)ның Казан ком-ты Казан губернасында кораллы күтәрелеш б-н җитәкчелек итә. Казанда *Революцион штаб* (26 окт.) һәм Вакытлы революцион ком-т төзелә; соңгысы идарә итү хокукын Вакытлы хөкүмәт хакимият башыннан бәреп төшерелгәннән соң рәисе итеп большевик Я.С.*Шейнкман* сайланган Казан Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советына тапшыра (к. *Казанда 1917 елгы октябрь кораллы баш күтәрелеше*). Идеологик дошманнары б-н көрәшү өчен, Казан большевиклары 1917 нең 8 декабрендә Г.Ш.Олькеницкий җитәкчелегендәге Революцион тикшерүләр комиссиясен төзиләр. Соңрак аның җирлегендә Гадәттән тыш хәлләр комиссиясе оеша. РСДРП(б)ның К.Я.Грасис җитәкчелегендәге Казан ком-ты 1918 нең февралендә Германия б-н сепарат килешүгә кул куюга каршы чыга һәм эсерлар, меньшевиклар һәм Мөселман социалистлар ком-ты б-н берлектә ХКС һәм БҮБКна адрес җибәрә. РКП(б)ның 7 нче съездыннан соң (1918) хәл кискен борылыш ала: Казан большевиклары гомуми карарга буйсына.

Татар большевиклары С.С.*Сәетгалиев*, К.Л.*Якубов*, Б.Җиһаншин, Х.Урманов, Г.С.*Касыймов* һ.б. Казанда узган (1918 нең гыйнв.-февр.) Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең икенче корылтаенда катнашалар һәм *Идел-Урал Штаты* (к. *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары*) төзелүгә каршы чыгалар. Мөселман оешмалары һәм большевиклары аеруча каршылык күрсәткән чорда корылтай президиумы башлыклары кулга алына (к. *«Болак арты республикасы»*). Килеп туган каршылыкны тулысынча хәл итү өчен, большевиклар К.Я.Грасис җитәкчелегендә Революцион штаб төзиләр. Төбәкнең милли үзенчәлекләргә ия булуы һәм милләтләрнең үзбилгеләнү (милли мохтарият) хокуклары турында лозунг игълан ителү сәбәпле, большевиклар, мөселман оешмаларының чыгышлары б-н көрәшеп, Идел-Урал Штаты идеяләренә башта «Идел-Урал Совет республикасы» (*Идел-Урал төбәге Советлары съездында*, Казан, 1918 нең 21–22 гыйн.) идеяләрен, аннары *Татар-Башкорт Совет Социалистик республикасы* (1918 нең 22 марты) идеяләрен каршы куярга тырышалар. Хакимияткә килгән беренче көннәреннән үк большевиклар планлы рәвештә барлык идарә оешмаларындагы җитәкче вазифа башкаручыларны үз партия әгъзалары б-н алыштыру сәясәте алып баралар. 1918 нең язында партия урыннарда актив рәвештә төзелеш эшләре башлап җибәрә: өяз һәм шәһәр ком-тлары, волость һәм авыл ячейкалары барлыкка килә. Ячейка партиянең беренчел оешмасы була. Июньдә Казан татар коммунистлары киңәшмәсендә *Россия мөселман коммунистлары партиясен* төзү инициативасы белдерелә, ҮК сайлана. РКП(б)ның Казан губерна ком-ты милли сепаратизмга каршылык күрсәтергә омтыла һәм губерна ком-ты каршында бюро җитәкчелегендәге татар коммунистлары секциясен оештыра. 1918 нең көзендә *Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының беренче Бөтенроссия съездында* (Мәскәү) М.Х.*Солтангалиев* һәм И.К.*Фирдәүс* мөселман коммунистларның РКП(б) составында үзләренең федератив башлангычтагы ҮКлары булган мөстәкыйль партияләрен саклап калу максаты б-н чыгыш ясыйлар. Шулай да РКП(б) басымы б-н съезд мөселман оешмаларының РКП(б) составына керүләре һәм аның бер өлешен тәшкил итүләре өчен тавыш бирә. Казанда алар партиянең Казан губерна ком-ты мөселман (татар) секциясе составына керәләр. Губерна ком-ты каршында ш.у. чуаш, мари, яһүд, чит ил коммунистлары (ш.у.к. *Казанда чит ил коммунистлары шөгъбәсе*) секцияләре оеша.

1918 нең җәендә Советлардан меньшевиклар һәм эсерлар куыла. Партия дәүләт органнары өчен кадрлар җыюга монополия ала. 1918 нең җәендә Казан губернасы *Гражданнар сугышы* үзәгенә әверелә. Губерна партия оешмасында ул вакытка 1 меңнән артык әгъза исәпләнә. 1918 нең 20 октябрендә гомумшәһәр партия конференциясе булып уза; аның карары нигезендә губерна ком-ты президиум һәм секретариаттан торырга тиеш була. Соңгысының вазифасына партия әгъзаларын исәпкә алу керә. Ком-т б-н РКП(б) ҮК тарафыннан билгеләнгән рәис җитәкчелек итә; еш кына алар төбәк үзенчәлекләре б-н таныш түгел кешеләр булалар һәм, нәтиҗәдә, аларның эшчәнлекләре кайвакыт оешма эчендәге татар һәм рус коммунистлары арасында аңлашылмаучанлыклар килеп чыгуга, аеруча милли сәясәт мәсьәләләренә карата ачыктан-ачык каршылыклар тууга китерә. Ком-тта оештыру, хәрби һәм нәшрият эшләре алып барыла. Секретарь каршында шәһәрдәге, авылдагы, кызылармиячеләр арасындагы эшләр буенча җаваплы оештыручылар; стат. бюросы эшли. 1918 нең октябре ахырыннан оешма РКП(б)ның Казан губерна оешмасы дип атала башлый. Партия инициативасы б-н 1919 ның апрелендә 1 нче шәһәр комсомол конференциясе уза (к. *Бөтенсоюз ленинчыл коммунистик яшьләр союзы*). Эшче һәм крәстиян хатын-кызлар арасында агитация һәм пропаганда эшләре алып бару өчен, апрельдән губерна ком-ты каршында хатын-кызлар секциясе бюросы эшли башлый, аның б-н Н.А.Ванькова, А.А.Титова, О.И.Цветкова, А.П.Шувалова җитәкчелек итә.

РКП(б)ның Казан оешмасы Уставы б-н (1919 ның 2 мартында кабул ителә) губерна ком-ты конференцияләр арасындагы дәвергә губернаның югары партия җитәкчелеге органы буларак билгеләнә, составында 7 әгъза һәм 4 канд. б-н 3 айга сайлана һәм башка оешмалар алдында партия вәкаләтлесе: өяз, волость, район партия оешмаларының, партия тормышының барлык тармакларына караган фракцияләрнең эшчәнлекләрен берләштерә һәм контрольдә тота, коммунист кадрларны губерна буйлап билгеләп чыга. 1919 ның 8 апрелендә губерна ком-ты бюросы хәрби, губерна, шәһәр бүлекләре, стат. бюросы оештыру турында карар кабул итә. 1919 ның августында авыл җирлегендә эшләү бүлеге раслана. 1919 ның октябрендә Казан губерна ком-ты штатында 1719 кеше исәпләнә. Барлык эш ике бүлек — губерна һәм шәһәр бүлекләре тарафыннан бүленеп башкарыла. Губерна ком-тының 1919 ел 31 декабрь карары б-н ком-т составы Казанның 13 өяз партия оешмалары вәкилләреннән һәм 14 район оешмалары вәкилләреннән сайлана, айга бер тапкыр чакырыла. Агымдагы эш өчен 17 әгъзадан торган бюро, секретариат һәм гомуми, агитация-пропаганда, оештыру-инструктор-

лык (мәгълүмати һәм барлау-билгеләү бүлекчәләре б-н), милли азчылык арасында эшләү, авыл җирендә эшләү, хатын-кызлар арасында эшләү бүлекләре, өмәләр бюросы, Махсус эш йөкләнгән частьлар һәм хәрби оешмалар советы була. 1920 нең гыйнварында губерна ком-ты каршында пропаганда һәм агитация бүлеге оеша, ш.у. мөселман бюросы эшли.

1919 ның мартында Башкортстан АССР барлыкка килгәннән соң, татар коммунистлары татар халкының дәүләтчелеге турындагы мәсьәләне кабат күтәреп чыгалар: 1919 ның октябрендә Казан татар коммунистларының — җыелышы, 1919 ның ноябрендә губерна конференциясе булып уза. РКП(б)ның Казан губерна ком-ты татарларның дәүләт булып оешуларына каршы була, партиянең кайбер губерна башкарма ком-ты әгъзалары һәм аның рәисе И.И.*Ходоровский* татарлар әле респ-ка б-н идарә итәргә әзер түгел, дип саныйлар. Татар коммунистлары арасында инде 1918 дә үк милли мәсьәләгә мөнәсәбәтле уңнар һәм сулларга бүленеш күзәтелә (шартлы бүленеш). Уңнар Татар-Башкорт респ-касы идеясен яклап чыгалар, Татарстан автономиясе төзелгәннән соң, милли сәясәтне актив рәвештә тормышка ашыруны алга сөрәләр. Суллар, киресенчә, автономияләштерүгә каршы чыгалар. Тикшеренүчеләр уңнарга — М.Х.Солтангалиев, К.Г.*Мохтаров*, Г.М.*Енбаев*, Р.Ә.*Сабиров*, Г.Г.*Мансуров*, М.Ю.Борындыков, М.К.Бөдәйли, Г.Г.*Максудов* һ.б.ны, сулларга М.С.Сәгыйдуллин, А.Я.Мөслимов, С.С.*Атнагулов*, Г.С.*Касыймов*, И.Галиев, М.*Әхмәтшин*, Ш.*Шәймәрданов* һ.б.ны кертәләр. Состав еш үзгәреп тора, кайберәүләр бер фракциядән икенчесенә күчә.

ТАССР барлыкка килү б-н бәйле һәм РКП(б) ҮК Политбюросының ТАССРның югары партия учреждениесе булып РКП(б)ның партия конференциясендә сайланган өлкә ком-ты торуын раслаган 1920 ел 8 июнь карарына ярашлы рәвештә, 1920 нең 23 августында губерна ком-ты үз вәкаләтләрен РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тына (к. *КПССның Татарстан өлкә комитеты*) тапшыра. Өлкә ком-тына барлык партия һәм совет органнары эшчәнлеге б-н җитәкчелек итү йөкләнә. Кантон ком-тлары, 1927–30 да партия оешмаларының район ком-тлары төзелә, аларның үз структуралары була. Ришвәтчелеккә каршы көрәш алып бару һәм партия әгъзаларының эш урыннарындагы гаепләрен ачыклау өчен, 1920 нең 15 ноябрендә өлкә контроль тоту комиссиясе оеша. Партиянең 10 нчы съезды карары б-н 1921 дә респ-када партияне «лаексыз элементлар»дан беренче чистарту уздырыла: 1570 кеше (24%) партиядән чыгарыла. 1920 елларда төрле дәрәҗәдәге партия оешмалары нигезенә наданлык б-н көрәш салынган *культура революциясен* гамәлгә ашыруда актив катнашалар; бу елларда илнең икътисадын торгызуга булышлык иткән ГОЭЛРО программасы да тормышка ашырыла башлый.

РКП(б)ның бөек державачылык шовинизмына һәм җирле милләтчелеккә каршы көрәшкә чакырган 12 нче съездыннан соң (1923 нең апреле) респ-када партиянең үз эчендә «милли тайпылыш»ка (М.Х.Солтангалиев, Г.Г.Мансуров, К.Г.Мохтаров, Г.М.Енбаев, Р.Ә.Сабиров һ.б.) каршы көрәш башлана, «тайпылыш» тарафдарлары РКП(б)ның И.В.Сталин тарафыннан уздырылган милли сәясәтенә каршы тәнкыйть б-н чыгалар. 1923 нең июнендә ҮК, М.Х.Солтангалиевне хөкем итү өчен, махсус киңәшмә (к. *РКП(б) ҮКның дүртенче киңәшмәсе*) уздыра.

1930 елларда *«солтангалиевчелек»*тә гаепләү репрессияләр өчен төп сәбәпкә әверелә. Солтангалиев партиядән чыгарыла. «Сул юнәлеш» төркеме дә (С.С.Атнагулов, М.С.Сәгыйдуллин һ.б.) ҮК һәм өлкә ком-ты тарафыннан тәнкыйтьләнә, аның әгъзалары милли нигилизмда гаепләнә. 1923 нең 19–21 июлендә өлкә ком-тының Казанның район ком-тларында һәм партиянең кантон ком-тларында җаваплы вазифалар башкаручы хезмәткәрләр б-н берлектә мухсус киңәшмәсе уза. ВКП(б) өлкә ком-тының 1 нче секретаре Д.Е.*Живов* доклад ясый. Киңәшмә тулысынча Солтангалиевне гаепләүгә багышлана. Өлкә ком-ты җитәкчелеге фикере буенча үзләренең эшчәнлекләрендә татар халкының милли үзенчәлекләре б-н исәпләшмәгән Слуцкий, Смирнов һәм Русинов та кискен тәнкыйтькә дучар булалар. 1923 нең 14 сентябрендә өлкә ком-ты пленумы булып уза, анда партия оешмасының партия һәм совет органнарының хезмәт иярәнә якынаюларын күздә тоткан милли төзелеш, татар телен гамәлгә кертү, пролетариатның милли кадрларын төзү, соц. милли мәдәният үсеше мәсьәләләре буенча эш планы кабул ителә (к. *Төпләндерү*).

Өлкә ком-ты алдына партиядәге татар коммунистларының санын арттыру бурычы куела. Өлкә партия оешмасында 1922 дә — 28,5%, 1925 тә 29,7% татар була. В.И.Ленинның вафатыннан соң, респ-када 1924 нең 15 февраленнән 15 маена кадәр Ленин чакыруы б-н партиягә алу уздырыла, партия әгъзаларының гомуми саны 5 мең кешегә җитә. 1920 елларда партиядә «эчке» дошманнар — милләтчеләр (солтангалиевчеләр), троцкийчылар, уңнар, суллар һ.б.га каршы актив көрәш бара. Партия өлкә ком-ты партия ҮК сәясәтен гамәлгә ашыра. Өлкә партия оешмасында бәхәсләр, Солтангалиевне гаепле дип табып, аны партиядән чыгарганнан соң да тынмый. ВКП(б) ҮКыннан респ-кага тикшерү максаты б-н В.В.Шмидт җитәкчелегендәге махсус комиссия килә. 1924 нең гыйнварында партия бюросы киңәшмәсе була, анда барлык татар партия әгъзаларын ышанычлылыкка тикшерү уздыру турында күрсәтмә бирелә. Моңа җавап рәвешендә берничә татар коммунисты *«Утыз тугыз җитәкче хаты»* язып җибәрергә карар кыла, анда татар коммунистларын кимсеткән дәлилләр күрсәтелә, 8 нче өлкә партия конференциясенең милли мәсьәләне хәл итәргә ышандырмавы турында әйтелә. Өлкә ком-ты карары нигезендә хатка кул куючылар барысы да милләтчелектә гаепләнә һәм тиздән «уңнар»ның җитәкчеләре Г.Г.Мансуров, М.Ю.Борындыков, К.Г.Мохтаров, Г.М.Енбаев, Р.Ә.Сабиров, түбәнрәк дәрәҗәдәге вазифалар башкару өчен, Мәскәүгә күчереләләр. Өлкә партия оешмасының үз эчендәге каршылык күп очракта ҮКның кадрлар билгеләү сәясәте дөрес куелмаган булу сәбәпле саклана, чөнки ул өлкә ком-ты секретаре вазифасын башкарырга еш кына респ-ка проблемалары б-н таныш булмаган кешеләрне (мәс., Пинсон, М.М.Хатаевич һ.б.) җибәрә. 1929 ның ноябрендә ВКП(б) өлкә ком-ты Пленумы булып уза, анда ВКП(б) ҮКның солтангалиевчелек б-н бәйле кешеләрне партия сафларыннан куу юнәлеше хуплана, шул рәвешчә К.Г.Мохтаров, Г.Г.Мансуров, Г.М.Енбаев партиядән чыгарыла. Н.И.Бухарин позициясен яклаучылар — А.Айхенвальд һәм В.Слепков та кискен тәнкыйтькә дучар була. Партия өлкә ком-ты халык хуҗалыгы үсешенә җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра, 15 нче съезд күрсәтмәләре нигезендә 1 нче бишьеллыкка план төзелә (1928–33). Партия инициативасы б-н халык хуҗалыгы үсешен тизләтүгә ярдәм итәргә тиешле соц. ярыш җәелдерелә. Коммунистлар тырышлыгы б-н колхозлар төзелә. *Крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерүне* тизләтү максатыннан ВКП(б) ҮК Пленумы карары нигезендә (1929 ның ноябре) авылларга 25 мең эшче, ТАССРның а.х. районнарына 400 эшче коммунист (В.П.Әхмәдуллин, Х.Б.Бәдретдинов, П.Г.Матвеев, В.А.Михайлов, В.С.Сәгъдетдинов һ.б.) җибәрелә. 1930 елларда партия үз сафларын чистарту эшләре алып бара, бу үз чиратында даими репрессияләргә әверелә. Партия коллегияләре каршында оператив хезмәткәр һәм тикшерүче вазифалары булдырыла. ТАССР буенча 4 оператив хезмәткәр һәм 3 тикшерүче була. Алар тарафыннан партия сафларында күпсанлы «партиягә каршы төркемнәр» булуы ачыклана, мәс., «Крәстиян иттифагы» («җитәкчеләре» Г.Әминов, М.С.Сәгыйдуллин) һ.б. шундыйлардан санала. 1933–34 тә өлкә оешмасының гомуми составыннан 12% партия әгъзасы чыгарыла. 1936 да документлар алыштыру уздырыла, шуның нәтиҗәсендә партия билетын нибары 14365 кеше генә кайтарып ала.

*Бөек Ватан сугышы* елларында партия үзенең эш рәвешен тулысынча үзгәртә, барлык көчләр дошманга каршы көрәш оештыруга юнәлтелә. Өлкә ком-тын үзгәртеп кору эше уздырыла, яңа бүлекләр төзелә, ВКП(б) өлкә ком-ты секретарьларының оборона, авиация, җиңел һәм җирле сәнәгать, транспорт, сәүдә һәм җәмәгать туклануы буенча вазифалары билгеләнә. 1941–42 дә фронтка респ-кадан 19645 коммунист (54%) китә. 1944 тә партия татар «милләтчелеге» б-н көрәшнең яңа этабына керә: *«Идегәй»* эпосы юбилеена әзерлек б-н бәйле рәвештә ВКП(б) ҮКның *«Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»* карары чыга, анда күп кенә тарихчылар һәм әдәбиятчылар Алтын Урда тарихын күпертеп күрсәтүдә гаепләнә. Татарстан өлкә ком-тының чираттагы Пленумында (1945 нең 24–27 февр.) Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты хезмәткәрләре тәнкыйтьләнә. Нәтиҗәдә, татар халкы тормышының бик күп чор-

ларына караган тарихын өйрәнү шактый елларга тыела.

Сугыштан соңгы чорда Татарстан өлкә оешмасының идарә структурасы гомуми система эшчәнлегендә әллә ни үзгәрешләргә китермәгән үзгәртеп коруларга дучар була. 1990 ның 30 августында ТАССР ЮС тарафыннан ТССР дәүләт суверенлыгы турында декларация кабул ителгәннән соң, 42 нче өлкә партия конференциясе 1990 ның 12 сентябрендә партия өлкә ком-тын КПССның Татарстан респ-ка ком-ты итеп үзгәртә. КПСС респ-ка ком-тының 1990 ел 1 декабрь карары нигезендә өлкә ком-тының структурасы үзгәрә, бүлекләр урынына комиссияләр төзелә. 1991 нең 6 ноябрендә РФ Президенты Б.Н.Ельцинның РФ терр-ясендә КПСС эшчәнлеген тыйган, аның оешма структураларын тарату һәм партия милкен дәүләт карамагына күчерү хакында игълан иткән «КПСС һәм РСФСР КП эшчәнлеге турында»гы Указы кабул ителү б-н КПССның Татарстан респ-ка оешмасы үзенең эшчәнлеген туктата.

Татарстан партия оешмасы эшчәнлеге тарихында барлыгы 8 губерна, 42 өлкә партия конференцияләре уздырыла. Матбугат органнары: *«Рабочий»*, *«Знамя революции»*, *«Бедняк»*, «Известия Казанского губкома РКП(б)», *«Красная Татария»*, *«Кызыл Татарстан»*, *«Социалистик Татарстан»*, *«Колхоз газетасы»*, *«Безнең байрак»*, *«Сугышчан алласыз»* һ.б. г-талар; *«Пути революции»*, *«Коммунист Татарии»*, *«Район газетасына ярдәмгә»*, *«Пропагандистка һәм агитаторга ярдәмгә»* һ.б. ж-ллар.

**1 нче кушымта**. Казан губернасы, ТАССР терр-яләрендә партия әгъзалары санының динамикасы (төрле елларда): 1917 дә — 650; 1918 дә — 1420; 1919 да — 1338, 1920 дә — 9268, 1924 тә — 2903; 1929 да — 9387, 1934 тә — 18682; 1939 да — 14483; 1945 тә — 28778; 1955 тә — 78511; 1970 тә — 170988; 1988 дә — 223013 кеше.

**2 нче кушымта**. РКП(б) Казан губерна оешмасының губерна конференцияләре:

**1 нче** губерна конференциясе — 1917 нең сентябре. Казанның 6 район ком-тыннан һәм 6 өяз ком-тыннан килгән делегатлар катнаша. ҮКның хакимиятне корал б-н кулга төшерү турындагы карары игълан ителүгә бәйле рәвештә хәрби тема төп мәсьәлә була. Оешма бөтен хакимиятнең Советларга күчүе өчен җитди көрәшкә әзер булуын белдерә. РСДРП(б)ның губерна ком-ты сайлана, ком-т каршында Н.Е.Ершов җитәкчелегендә хәрби бүлек төзелә.

**2 нче** губерна конференциясе. Мәгълүматлар юк.

**3 нче** губерна конференциясе — 1918 нең 28 октябре. 42 делегат. Көн тәртибе: губерна ком-тының эше турында хисап, агымдагы вазгыять, РКП(б) ячейкалары төзелү, Кызыл Армия частьлары, авыл ярлылары ком-тлары оешу хакында докладлар. РКП(б)ның Казан губерна оешмасы Уставы кабул ителә. Конференциядә Козьмодемьянск (86 партия әгъзасы), Лаеш (38), Мамадыш (99), Зөя, Спас (72), Тәтеш (71), Царёвококшайск (45), Цивильск (10), Чабаксар, Чистай (210), Ядрин (72) өяз ком-тлары расслана. Устав буенча өяз ком-ты җитәкчедән (рәис), секретарь, казначей, коммунистлар клубы мөдиреннән тора. Составында 20 дән күбрәк партия әгъзасы булган һәр ячейка мөстәкыйль рәвештә партия билеты бирү хокукына ия була.

**4 нче** губерна конференциясе — 1919 ның 2 марты. Көн тәртибе: авылда эшләү, хезмәт һәм партия дисциплинасы, рус милләтеннән булмаган хезмәт ияләре арасында эшләү, Советларның губерна съездын әзерләү, партиянең 8 нче Бөтенроссия съезды турында докладлар. РКП(б)ның Казан губерна оешмасы Уставы кабул ителә. Губерна ком-тының яңа составы сайлана.

**5 нче** губерна конференциясе — 1919 ның 6–8 июле. 120 делегат. Көн тәртибе: губерна ком-тының эше турында хисап. Колчакчылар б-н көрәш вакытында оешма башкарган эшләргә нәтиҗә ясала һәм якын киләчәккә бурычлар билгеләнә. Эшчеләр сыйныфы б-н урта катлау крәстияннәр арасындагы берлекне ныгыту, милли азчылык һәм хатын-кызлар арасында партия-сәясәт эшчәнлеге алып бару, комсомол йогынтысын көчәйтү турында карарлар кабул ителә.

**6 нчы** губерна конференциясе. Мәгълүматлар юк.

**7 нче** губерна конференциясе — 1920 нең 12–14 гыйнвары. 180 делегат. Губерна ком-тының эше турында хисап. Карар: өяз партия оешмалары б-н мөнәсәбәтне ныгытырга, партия дисциплинасын көчәйтү чаралары күрергә; татарлар, чуашлар, марилар, ш.у. хатын-кызлар һәм яшьләр арасында эшне көчәйтергә. Конференция эшендә хуҗалыктагы бөлгенлеккә каршы көрәш б-н бәйле мәсьәләләр үзәк урынны алып тора. Губерна ком-тының яңа составы сайлана. Конференция карары б-н губерна ком-ты каршында секретариат һәм агитация-пропаганда, оештыру-инструкторлык, авылда һәм хатын-кызлар арасында эшләү бүлекләре, ш.у. өмәләр бюросы һәм милли секцияләр оеша. Өяз ком-тларын яңартып кору турында карар кабул ителә: алар каршында секретариат, бүлекләр (мәгълүмат, авылда һәм хатын-кызлар арасында эш б-н тәэмин итү, өмәләр бюросы) һәм мөселман секцияләре булдырыла.

**8 нче** губерна конференциясе — 1920 нең 3 марты. Гадәттән тыш конференция. Төп мәсьәлә — РКП(б)ның 9 нчы съездына делегатлар сайлау.

**3 нче кушымта**. ВКП(б), КПСС Татарстан өлкә оешмаларының өлкә конференцияләре:

**1 нче** өлкә конференциясе — 1920 нең 23–25 августы. 177 делегат. Көн тәртибе: губерна ком-ты хисабы, агымдагы вазгыять турында доклад, азык-төлек һәм оештыру мәсьәләләре. Өлкә ком-ты составындагы мөселман бюросын ябу хакындагы мәсьәлә бәхәс уята. Партияне милли үзенчәлекләр буенча бүлү ягында булган М.Ю.Борындыков һәм кайбер делегатлар бюроны саклап калуны яклап чыгалар. Дәвамлы бәхәсләрдән соң күпчелек аны ябарга кирәклеге турында әйтә. Партия өлкә ком-тының яңа составы сайлана.

**2 нче** өлкә конференциясе — 1921 нең 22–26 феврале. 158 делегат. Көн тәртибе: өлкә ком-ты, контроль һәм ревизия комиссияләре хисаплары, «Капиталистик чолганыштагы Совет Россиясе» темасына докладлар, партия һәм хуҗалык төзелеше бурычлары, милли мәсьәләне чишүдә партиянең чираттагы бурычлары, профсоюзлар һәм хуҗалык тормышында аларның роле. «Милли мәсьәләгә карата партиянең чираттагы бурычлары турында» доклад б-н С.Сәетгалиев чыгыш ясый, милли мәдәният үсеше, татар телен гамәлгә кертү, хезмәт ияләре арасында партия эше турындагы мәсьәләләрне күтәреп чыга. Шулай да ул милләтчелек б-н көрәшне алгы планга чыгара, шовинизм проблемаларын читләтеп үтә. Татар халкының принципиаль мәсьәләләре каралмый. Күп кенә татар коммунистлары җавап рәвешендә өлкә ком-ты җитәкчелегенә милли сәясәтне тормышка ашыру мәсьәләләренә карата катгый шелтә белдерәләр. Өлкә ком-ты җитәкчеләренең милли проблемаларның асылына төшенә алмауларына да басым ясала. «Милли мәсьәлә турында» карар кабул иткәндә тәнкыйть сүзләре исәпкә алынмый, ул гомуми һәм берьяклы характерда була. Нигезләмәләрнең берсе түбәндәгечә яңгырый: «Милли тайпылышларга каршы көрәштә хезмәт ияләре арасында партия эшчәнлеген көчәйтү». Конференциядә ш.у. профсоюзларның роле турындагы сорау да карала; монда ҮКтагы кебек үк өч төрле караш чагылыш таба: троцкийчылар («әйе» дип тавыш бирүчеләр — 5 кеше), «эшчеләр оппозициясе» («әйе» — 3 кеше), ленинчыл караш (күпчелек тавыш җыя — 150 кеше). Өлкә ком-тының яңа составы һәм партиянең 10 нчы съездына делегатлар сайлана.

**3 нче** өлкә конференциясе — 1921 нең 23–24 июне. 226 делегат. Көн тәртибе: өлкә ком-ты хисабы, икътисад өлкәсендәге һәм профсоюзлар хәрәкәте буенча бурычлар, ТАССР ҮБК һәм ХКСның коммунистлар фракцияләре турында докладлар. РКП(б)-ның 10 нчы съезды карарларын гамәлгә ашыру буенча чыгарылган беренче нәтиҗәләргә йомгак ясала. Аларда Россия халыклары арасында сәяси-икътисади тигезсезлекне бетерү зарурлыгы турында игълан ителгән була. Бу «уң» татар коммунистларына милли мәсьәләне яңадан кузгату һәм С.С.Сәетгалиев үткәргән милли сәясәтне гаепләп чыгу мөмкинлеге бирә. Нәтиҗәдә, С.С.Сәетгалиев партиянең яңа өлкә ком-ты составына сайланмый, «уң» коммунистлардан аның составына К.Г.Мохтаров һәм Р.Ә.Сабиров уза. Конференция татар халкы арасында эш барышын көчәйтү, комиссиянең татар телен гамәлгә кертү буенча эшчәнлегенә зур игътибар бирү кирәклеген тәкъдим итә. Өлкә ком-тының яңа составы сайлана.

**4 нче** өлкә конференциясе — 1921 нең 1–4 декабре. 193 делегат. Көн тәртибе: өлкә ком-ты (Д.А.Орлов), контроль һәм ревизия комиссияләре хисаплары, халыкара хәл (Д.Е.Живов), ТАССРның якын киләчәктәге

хуҗалык сәясәте (В.Сериков, А.Злобин), яңа курс шартларында партия-оешма эше, агитация һәм пропаганда куелышы (С.З.Слуцкий), товар алмашу нәтиҗәләре һәм перспективалары (И.Ефимов) турында докладлар. Җимереклек һәм ачлыкны бетерү юллары хакында фикер алышу (к. *Ачлык* (1921–22). Барлык көч һәм чараларны азык-төлек мәсьәләсен яхшыртуга, эчке ресурсларны дөрес файдалануга юнәлтү; җәмәгать тукланууын оештыру, киң масса хезмәт ияләрен ачлыктан интегүчеләргә ярдәм күрсәтү һәм халык хуҗалыгын торгызу эшләренә җәлеп итү турында карар чыгарыла.

**5 нче** өлкә конференциясе — 1922 нең 16–20 марты. 102 делегат. Көн тәртибе: өлкә ком-ты (А.П.Галактионов), контроль һәм ревизия комиссияләре (И.Б.Понеделко, А.В.Недачин) хисаплары, Коминтернның халыкара хәле һәм тактикасы (С.З.Слуцкий), массаларда партия эше (Д.Е.Живов), профсоюзлар (Д.А.Орлов) турында докладлар. Карарлар: барлык партия оешмаларына да а.х.н торгызу эшендә катнашырга, РКП(б) ячейкаларын ныгытырга, партиянең советлар, профсоюзлар, комсомол б-н җитәкчелеген яхшыртырга. Конференция троцкийчылар оппозициясенә һәм аның ТАССРдагы әгъзаларына шелтә белдерә. Өлкә ком-тының яңа составы һәм РКП(б)ның 11 нче съездына делегатлар сайлана.

**6 нчы** өлкә конференциясе — 1922 нең 16–18 октябре. 170 делегат. Көн тәртибе: өлкә ком-ты (Д.Е.Живов), контроль һәм ревизия комиссияләре (В.А.Кальченко, А.В.Недачин) хисаплары, халыкара хәл торышы (А.Г.Шляпников, А.Н.Декапольский), ТАССРда хуҗалык төзелеше перспективалары, ачлык б-н көрәш нәтиҗәләре һәм комиссиянең ачлык нәтиҗәләрен бетерүдә бурычлары (Е.Н.Забицкий), агитация һәм пропаганданы җәелдерү эшендә партия оешмасының чираттагы бурычлары турында докладлар. Сәнәгать, а.х.н торгызуны, хезмәт ияләре арасында массакүләм агитация эшләрен көчәйтүне тизләтүче чаралар эшләнә. Өлкә ком-ты бюросы сайлана (Б.Галл, Д.Е.Живов, Д.Орлов, Я.Чанышев).



6 нчы өлкә партия конференциясендә сайланган Татарстан партия өлкә комитеты.

**7 нче** өлкә конференциясе — 1923 нең 22–26 марты. 142 делегат. Көн тәртибе: өлкә ком-ты (Д.Е.Живов), контроль һәм ревизия комиссияләре (В.С.Шерепов, А.В.Недачин) хисаплары, ТАССРда сәнәгать торышы, партия һәм совет төзелешендә миллилек чаткылары, авылда салым сәясәте турында докладлар. Өлкә ком-тының яңа составы һәм РКП(б)ның 12 нче съездына делегатлар сайлана.

**8 нче** өлкә конференциясе (чираттан тыш) — 1924 нең 20–23 марты. 144 делегат. Көн тәртибе: 13 нче Бөтенсоюз партия конференциясе турында хисап (И.Т.Морозов), өлкә ком-ты (И.М.Бажанов), контроль һәм ревизия комиссияләре хисаплары. Конференция делегатлары «троцкийчылар» һәм «аумакай милләтчеләрне» гаепләп чыгыш ясыйлар. Конференция карарлары: РКП(б) әгъзаларын ленинчыл рухта тәрбияләргә, партия аппаратын ныгытырга, марксизм-ленинизм теориясен тирәнтен өйрәнергә, авылда эшне көчәйтергә. Өлкә ком-тының яңа составы сайлана. РКП(б)ның 12 нче съезды карары б-н ТАССРда бердәм партия-дәүләт контроль органы — Контроль халык комис-тының Эшче-крәстиян инспекциясе оеша (ОКК-РКИ).

**9 нчы** өлкә конференциясе — 1924 нең 13–15 мае. 309 делегат. Көн тәртибе: өлкә ком-ты (И.П.Морозов), контроль комиссиясе (А.В.Недачин, А.В.Жуков) хисаплары, эчке сәүдә һәм кооперация (А.Н.Злобин), партия төзелеше, милли сәясәт (З.З.Гыймранов), яшьләр арасында эшләү (П.Н.Павлов) турында докладлар. Өлкә ком-ты секретаре И.Т.Морозов үз докладында К.Г.Мохтаров, Г.Г.Мансуров, Г.М.Енбаевны өлкә партия оешмасында сәламәт булмаган атмосфера тудыруда гаепли һәм партиянең ҮКына Мохтаровны хөкүмәт җитәкчелеге вазифасыннан азат итүләрен сорарга кушып мөрәҗәгать итә. Ул бу кешеләрнең дәүләт органнарына эшкә буржуазия калдыкларын, ш.и. элек совет хакимиятенә каршы булган кешеләрне дә алуларын билгеләп үтә. Делегатлар партиянең милли мәсьәләне яктырткан программасын тормышка ашыру турындагы карарны раслыйлар, төркемчелекне кискен тәнкыйтьлиләр. РКП(б)ның 13 нче съездына делегатлар сайлана.

**10 нчы** өлкә конференциясе — 1925 нең 1–3 гыйнвары. 302 делегат. Көн тәртибе: ҮК һәм Үзәк контроль комиссиясе һәм РКП(б) Контроль халык комис-тының Эшче-крәстиян инспекциясе (И.М.Варейкис, Н.Ф.Панов), өлкә ком-ты (И.Т.Морозов), контроль һәм ревизия комиссияләре (Г.Ф.Бердников, А.В.Недачин), хатын-кызлар бүлеге (Е.Павлова) хисаплары, авылда һәм яшьләр арасында эшләү (И.Бажанов, П.Павлов), ТАССР сәнәгате (А.Л.Колосов) турында хисаплар. Конференция авылда эшләү — крәстиян массаларын һәрьяклап кооперацияләштерү бурычын күздә тоту турында карар чыгара. Делегатлар троцкийчылар оппозициясен гаеплиләр һәм барлык аумакайларга каршы көрәшкә әзер булулары турында игълан итәләр.

**11 нче** өлкә конференциясе — 1925 нең 8–12 декабре. 322 делегат. Көн тәртибе: өлкә ком-ты (К.А.Ратехин), контроль һәм ревизия комиссияләре (И.М.Бажанов, А.М.Колосов) хисаплары, РКП(б) ҮК һәм Үзәк контроль комиссиясе — Эшче-крәстиян инспекциясе (ЦКК-РКИ, П.Новиков), ТСПС фракциясе (К.Ратехин) докладлары, Татарстанда халык хуҗалыгының торышы һәм перспективасы (Х.Габидуллин), хәрби төзелеш (Я.Чанышев), Россия ленинчыл коммунистик яшьләр союзында (РЛКСМ) партия эшчәнлеге (Д.Бендюков) турында докладлар. Делегатлар партиянең үз эчендә эшчәнлекне көчәйтү, киң катлау эшче һәм крәстиян массалары, советлар, профсоюзлар, комсомол б-н тыгыз элемтәләр урнаштыру, оешманың социаль составын тәртипкә китерү зарурлыгын ассызыклыйлар. Зиновьевчыларның Ленинградтагы чыгышларына карата шелтә белдерәләр. Өлкә ком-тының яңа составы һәм РКП(б)ның 14 нче съездына делегатлар сайлана.

**12 нче** өлкә конференциясе — 1926 ның 27 декабре — 1927 нең 1 гыйнвары. 239 делегат. Көн тәртибе: өлкә ком-ты (М.М.Хатаевич), контроль һәм ревизия комиссияләре (П.Новиков, Г.Ф.Фәсхетдинов) хисаплары, ТАССР ХКС рәисе Х.З.Габидуллинның «ТАССРда хуҗалык үсешенең төп моментлары турында» докладлы. ВКП(б) ҮК секретаре С.В.Косиор катнаша. Конференциядә респ-када халык хуҗалыгы төзелешен торгызу дәверенең тәмамлануы турында игълан ителә. Делегатлар ВКП(б) ҮКның индустрияләштерүгә юнәлтелгән ген. линиясен хуплыйлар һәм троцкийчы-зиновьевчылар блогы чыгышларына карата шелтә белдерәләр. Авылда әкренләп коллективлаштыру процессы башлануга игътибар итәләр. 1926–27 дә хезмәт ияләрен респ-када халык хуҗалыгының барлык тармаклары үсешенә тулысынча әзерләү юнәлешендә төгәл чаралар билгеләнә.

**13 нче** өлкә конференциясе — 1927 нең 23–29 ноябре. 230 делегат. Көн тәртибе: өлкә ком-ты (М.М.Хатаевич), контроль һәм ревизия комиссияләре (Г.Ф.Фәсхетдинов, Н.Н.Фокин), ҮК һәм ВКП(б)ның Үзәк контроль комиссиясе (А.И.Догадов, С.О.Викснин) хисаплары, авылда эшләү турында доклад (К.Гарифуллин). Хисаплар буенча фикер алышканда троцкийчы-зиновьевчылар блогы тарафдарлары Я.С.Щербинин, Н.Д.Кочкарин һәм Левин («83 нче платформа»га кул куючылар) чыгыш ясыйлар, алар үз резолюцияләре проектын алга сөрәләр һәм партиядән чыгарылган оппозиционерларны яңадан кайтаруны таләп итәләр. Шулай да алар фикерләре хуплау тапмый, конференция оппозиционерларны гаепли һәм өлкә ком-ты юнәлешен дөрес дип таба, аның гамәли эшчәнлеген канәгатьләнерлек дип бәяли. Өлкә



9 нчы өлкә партия конференциясе. Казан. 1924, май.

ком-тының яңа составы (71 әгъза һәм 35 канд.) һәм ВКП(б)ның 15 нче съездына делегатлар сайлана.

**14 нче** өлкә конференциясе — 1929 ның 5–13 гыйнвары. 415 делегат. Көн тәртибе: өлкә ком-ты (М.О.*Разумов*), контроль комиссиясе (И.А.Лычёв) хисаплары, Халык игенчелек комис-тының «ТАССРда авыл хуҗалыгы торышы һәм аның бишьеллык план б-н бәйле үсеш перспективалары турында» доклады (Н.Петров). Кулакларга каршы көрәшне көчәйтү, аларның изүчелек тенденцияләрен чикләү, күмәкләштерүне тизләтү зарурлыгы ассызыклана. Өлкә ком-тының яңа составы сайлана (71 әгъза һәм 35 канд.).

**15 нче** өлкә конференциясе — 1930 ның 5–15 июне яки 5–13 июне. 501 делегат. Көн тәртибе: өлкә ком-ты (М.О.Разумов), ҮК (А.И.Догадов), ВКП(б)ның Үзәк контроль комиссиясе (С.А.Новосёлов) хисаплары, комсомол оешмасы эшчәнлеге турында хисап, «ТАССР авыл хуҗалыгын социалистик үзгәртүнең нәтиҗәләре һәм алдагы бурычлары», «Үзгәртеп корулар чорында профсоюзларның бурычлары» докладлары. Конференциядә ТАССР а.х.на карата «уң оппортунистларның ярлылык теориясе» тәнкыйтьләнә (В.Исхаков). Делегатлар Өлкә контроль комиссиясенә партияне оппортунистлардан чистарту эшендә ныклы көрәшне дәвам итү бурычын йөклиләр. 1929 да башланган ВКП(б) сафларын чистарту эшенә беренче нәтиҗәләр ясала, 8% әгъза чыгарыла. Конференция колхоз төзелешен ныкыту һәм киңәйтү зарурлыгын билгеләп үтә. Өлкә ком-тының яңа составы һәм ВКП(б)ның 16 нчы съездына делегатлар сайлана.

**16 нчы** өлкә конференциясе — 1932 нең 23–28 гыйнвары. 550 делегат. Көн тәртибе: өлкә ком-ты, контроль һәм ревизия комиссияләре, комсомол хисаплары. Конференция партия әгъзаларын бишьеллык планны вакытыннан алда үтәү өчен көрәштә эшчеләр, колхозчылар һәм интеллигенциянең үсеп баручы активлыгына җитәкчелек итәргә чакыра. Конференция нәтиҗәләре нигезендә партия һәм совет активын әзерләү һәм яңадан әзерләү курслары оеша. Өлкә ком-тының яңа составы сайлана.

**17 нче** өлкә конференциясе — 1934 нең 17–22 гыйнвары. 533 делегат. Көн тәртибе: өлкә ком-ты (А.К.*Лепа*), контроль һәм ревизия комиссияләре хисаплары, капиталь төзелеш турында хисап, оештыру мәсьәләләре. Конференция Татарстан шартларында партиянең милли сәясәтен уздыру мәсьәләсенә зур игътибар бирә: бөекдержавачылык шовинизмы да, ш.у. җирле милләтчеләр дә гаепләнә. Карарда татар халкының алга таба форма ягыннан милли һәм эчтәлек ягыннан соц. мәдәни үсеше респ-ка үсешенең төп шартларыннан берсе булуы ассызыклана. Сәнәгать пр-тиеләренең партия ком-тлары алдына партия һәм тәрбия эшен яхшырту, коммунистларның алга таба үрнәк күрсәтүләрен үстерүне тәэмин итү бурычы куела. Карарда профсоюзлар эшен тиз арада үзгәртеп кору һәм аларны җитештерүгә якынайту, соц. ярышлар җәелдерү, хезмәт иярләренең мәдәни-көнкүреш хаҗәтләрен канәгатьләндерүне көчәйтү таләбе куела. Өлкә ком-тының яңа составы (107 әгъза һәм 54 канд.) һәм ВКП(б)ның 17 нче съездына делегатлар сайлана.

**18 нче** өлкә конференциясе — 1937 нең 10–18 июне. 478 делегат. Конференциядә күпчелек партия хезмәткәрләренең, хуҗалык мәсьәләләре б-н мавыгып, партия эшчәнлеген көчсезләндерүләре, коммунистлар сафыннан аерылулары турында билгеләп үтелә. Кабул ителгән карарларның үтәлеше тиешле дәрәҗәдә контрольдә булмый. Карар: сәнәгать б-н җитәкчелек итүнең сәяси һәм хуҗалык-техник дәрәҗәсен үстерергә, колхозларның алга таба ныкыгуы, а.х.ның барлык тармаклары үсеше буенча эшчәнлекне көчәйтергә, партия пропагандасын, хезмәт иярләренә интернациональ тәрбия бирүне нигездән яхшыртырга, милләтчелек һәм шовинизмның барлык һәм төрле чагылышлары б-н аяусыз көрәшергә. Барлык партия ком-тларының да коммунистлар алдында җавап тотарга, даими рәвештә актив җыелышлары җыярга, партия карарларының үтәлеше буенча җитди тикшерү алып барырга, партия Уставын, демократик үзәкләштерү системасын, ш.у. сайлау принципларын аз гына да бозарга маташу очракларын төптән кисәтергә тиешлеге күрсәтелә. Шәһәр һәм авыл хезмәтчәннәрен илне сакларга әзерләүгә, Осоавиахим һәм башка иҗтимагый оешмаларның эшчәнлекләрен активлаштыруга аеруча зур игътибар бирелә.

**19 нчы** өлкә конференциясе — 1938 нең 10–19 июне. 504 делегат. Халык хуҗалыгы казанышлары, а.х. торышы хакында фикер алышалар. 1937 дә сәнәгать җитештерүе планы үтәлмәүгә китергән кимчелекләрне анализлап һәм а.х.ның алга таба үсеше мәсьәләләре хакында фикер алышып, конференциядә катнашучылар партия-сәясәт һәм массакүләм агитация эшләрен камилләштерүче чараларны билгелиләр. Өлкә ком-тының яңа составы сайлана.

**20 нче** өлкә конференциясе — 1939 ның 25 феврале — 2 марты. 514 делегат. Көн тәртибе: «СССР халык хуҗалыгы үсешенең өченче бишьеллык планы», «ВКП(б) Уставындагы үзгәрешләр» докладларының тезислары буенча фикер алышу. Алар тулысынча делегатлар тарафыннан хуплана һәм ТАССР халык хуҗалыгы үсешенең бишьеллык планын эшләгән вакытта нефть эзләүне киңәйтү, чимал һәм файдалы казылмаларның җирле төрләреннән аеруча нәтиҗәле файдалану, киң кулланылыштагы товарлар чыгаруны арттыру өчен җирле ресурсларны югары дәрәҗәдә мобильләштерүне исәпкә алу, а.х. өлкәсендә бөртекле культуралар уңдырышлылыгын яхшыртуны төп бурыч итеп кую, дөрес чәчү әйләнеше кертү, комплекслы механикалаштыруны гамәлгә ашыру, терлекләр санын арттыру һәм аның сыйфатын күтәрү кебек бурычлар күздә тотылган кайбер искәрмәләр һәм өстәмәләр кабул ителә. ВКП(б)ның 18 нче съездына делегатлар сайлана.

**21 нче** өлкә конференциясе — 1940 ның 10–15 марты. 494 делегат. 1939 да халык хуҗалыгы үсеше турында хисап. 3 нче бишьеллык планының соңгы ике елына нәтиҗәләр чыгарыла. Конференциядә барлык партия оешмаларыннан халык хуҗалыгы планнарын тормышка ашыру буенча кыю чаралар күрү, хезмәт иярләре арасында сәяси эшчәнлекне яхшырту, соц. ярышны киңрәк җәелдерү, алдынгы тәҗрибәне катгый рәвештә гамәлгә ашыру таләп ителә. Өлкә ком-тының яңа составы сайлана.

**22 нче** өлкә конференциясе — 1948 нең 30 марты — 1 апреле. 587 делегат. Көн тәртибе: 1940–48 елларга өлкә ком-ты хисабы. Өлкә партия оешмасының респ-каның барлык хезмәт иярләренә сугыштан соңгы беренче бишьеллыкка планнарның 4 ел эчендә үтәлүенә этәргеч бирүне күздә тоткан төп бурычы билгеләнә, партия-оешма һәм идеология эшчәнлекләренең төгәл чаралары билгеләнә.

**23 нче** өлкә конференциясе — 1950 нең 28–30 марты. 593 делегат. Өлкә ком-ты хисабы. Ирешелгән нәтиҗәләргә карамастан, ВКП(б) өлкә ком-тының һәм ТАССР МСның кимчелекләрдән тулысынча арынмаулары билгеләп үтелә: барлык пр-тиеләр дә

үз алларына куелган җитештерү бурычларын үтәмәгән, респ-каның а.х. ашлык җитештерү планын башкарып чыга алмаган. ВКП(б) ҮК карарларын тормышка ашыруны тәэмин итәргә тиешле гамәли чаралар программасы раслана. Өлкә ком-тының яңа составы сайлана.

**24 нче** өлкә конференциясе — 1952 нең 18–20 сентябре. 714 делегат. Конференциядә ВКП(б) ҮК проектлары: «СССРның 1951–1955 еллар өчен бишьеллык үсеш планы буенча 19 нчы съезд күрсәтмәләре» һәм «Партиянең үзгәртелгән Уставы тексты», өлкә ком-ты хисаплары карала. Проектлар хуплана, өлкә ком-тының, тикшерү комиссиясенең яңа составы, ВКП(б)ның 19 нчы съездына делегатлар сайлана.

**25 нче** өлкә конференциясе — 1954 нең 15–16 феврале. 745 делегат. Хуҗалык, мәдәният, партия-оешма һәм сәяси эшчәнлек б-н җитәкчелек итүдә җитди кимчелекләр билгеләп үтелә, ТАССРның партия оешмалары эшчәнлеге үзәгендә кадрлар сайлау һәм билгеләү, эшчәнлекне тикшерү, соц. ярыш оештыру, алдынгы хезмәт ысулларын гамәлгә кертү мәсьәләләре торырга тиешлеге ассызыклана. Өлкә ком-тының яңа киңәйтелгән составы сайлана.

**26 нчы** өлкә конференциясе — 1956 ның 10–11 гыйнвары. 838 делегат. 1954–55 елларга нәтиҗә чыгарыла. Өлкә ком-тының яңа составы һәм партиянең 20 нче съездына делегатлар сайлана.

**27 нче** өлкә конференциясе — 1957 нең 10–11 декабре. 788 делегат. Партиянең 20 нче съезды карарлары тормышка ашырылганнан соң, өлкә, шәһәр һәм район ком-тларының идарә итү стиле һәм ысулы яхшыру турында билгеләп үтелә.

**28 нче** өлкә конференциясе — 1959 ның гыйнвары. 593 делегат. Соңгы 5 ел эчендә респ-када а.х. торышы һәм алдагы елларга үсеш планы мәсьәләләре карала.

**29 нчы** өлкә конференциясе — 1960 ның 26–27 гыйнвары. Нәтиҗәләр чыгару.

**30 нчы** өлкә конференциясе — 1961 нең 26–27 сентябре. 1069 делегат. Өлкә партия оешмасының оештыру һәм сәясәт эшчәнлеген көчәйтүгә, хуҗалык һәм мәдәният б-н җитәкчелек итү дәрәҗәсе үсешенә ирешүе билгеләп үтелә. КПССның 22 нче съездына делегатлар сайлана.

**31 нче** өлкә конференциясе — 1963 нең 26–27 ноябре. 1122 делегат. Конференциядә партиянең мәдәни төзелеш, халык мәгарифе, фән б-н җитәкчелек итүенә зур игътибар бирелә.

**32 нче** өлкә конференциясе — 1966 ның 16–18 феврале. 791 делегат. Җидееллыкка нәтиҗәләр чыгарыла. КПССның 23 нче съездына делегатлар сайлана.

**33 нче** өлкә конференциясе — 1968 нең 21–22 феврале. 810 делегат. Бишьеллыкның беренче ике елындагы эш турында фикер алышу.

**34 нче** өлкә конференциясе — 1971 нең 15–16 феврале. 788 делегат. 8 нче бишьеллыкка нәтиҗәләр чыгару. 1971–75 елларга халык хуҗалыгы үсеше планын кабул итү.

**35 нче** өлкә конференциясе — 1974 нең 26–27 феврале. 779 делегат. 9 нчы бишьеллыкның беренче өч елына нәтиҗәләр ясала.

**36 нчы** өлкә конференциясе — 1975 нең 25–26 декабре. 792 делегат. 9 нчы бишьеллыкның нәтиҗәләре, 1976–80 елларга халык хуҗалыгының үсеш планы карала.

**37 нче** өлкә конференциясе — 1978 нең 21 декабре. 1976–78 елларга хисап.

**38 нче** өлкә конференциясе — 1980 нең 24–25 декабре. 835 делегат. 10 нчы бишьеллыкның эш нәтиҗәләре, 1981–85 кә халык хуҗалыгының үсеш планы карала.

**39 нчы** өлкә конференциясе — 1984 нең 14 гыйнвары. 869 делегат. 1981–83 кә нәтиҗәләр ясала.

**40 нчы** өлкә конференциясе — 1986 ның 17–18 гыйнвары. 717 делегат. Көн тәртибе: өлкә ком-ты, ревизия комиссиясе хисаплары, КПСС Программасының яңа редакциясе проекты, КПСС Уставындагы үзгәрешләр, 1986–90 елларга һәм 2000 гә кадәрге яхшы якка үзгәрешләргә мөнәсәбәтле СССРның икътисади һәм социаль үсешенең төп юнәлешләре проекты турында докладлар. Партиянең 27 нче съездына делегатлар сайлана.

**41 нче** өлкә конференциясе — 1988 нең 23–24 декабре. 698 делегат. КПСС өлкә ком-ты, ревизия комиссиясе эшчәнлекләре турында хисаплар. Кабул ителгән карарда партиянең ТАССР өлкә ком-ты, шәһәр һәм район ком-тларының үзгәртеп корыларда тоткарлык механизмын ахыргача җимереп чыга, һәрбер хезмәт коллективында даими иҗади атмосфера тудыра, икътисади реформаны тормышка ашыруның нәтиҗәле юлларын эзли, хезмәтне оештыруның алдынгы формаларын үзләштерә, чын хуҗалык исәп-хисабын булдыра алмаулары билгеләп үтелә.

**42 нче** өлкә конференциясе — 1990 ның 1–2 июне (1 нче өлеше), 12 сентябре (2 нче өлеше). Көн тәртибе: 1) партиянең 28 нче съездына КПСС ҮК Платформасының «Гуманлы, демократик социализмга» проекты турында; 2) КПСС Уставы проекты турында; 3) КПССның 28 нче съездына делегатлар сайлау турында; 4) өлкә ком-ты, ревизия комиссиясе хисаплары; 5) өлкә ком-тына һәм ревизия комиссиясенә сайлаулар. «Партиянең 28 нче съездына әзерлек барышы турында»гы карарда «илдәге көчәеп баручы кризис күренешләренең, үзгәртеп корулар вакытындагы хаталарның партиягә, аның халык арасындагы абруена тискәре йогынты ясавы, КПСС эчендә төрле идеяне хуплаучы юнәлешләр һәм агымнарның көчле тәэсире сизелү, партия сафларыннан үз теләкләре б-н китүчеләрнең саны арту» билгеләп үтелә. Тәкъдим ителгән Платформадагы нигезләмәләрнең бер өлешенең инде искергән булуы турында әйтелә. Шул рәвешчә автономияләрнең хокуклары киңәю турындагы нигезләмәләр рәсми характерга ия була һәм респ-каның ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерми. Татарстанның күпчелек коммунистлары ленинчыл типтагы партия буларак яңартылган КПССны, соц. сайлауга чын күңелдән бирелгәнлекне яклап чыга. Союздаш һәм автономияле респ-каларның илнең икътисади, социаль һәм мәдәни тормышына караган мәсьәләләрне чишкәндә тигез хокукларга ия булулары турындагы нигезләмәләрнең КПСС Платформасына кертелергә тиешлегенә басым ясала.

Чыг.: Большевики Татарии в годы иностранной военной интервенции и гражданской войны (Август 1918 – декабрь 1920): Сб. док. и материалов. К., 1961; Летопись борьбы и свершений: Хроника партийной организации Татарии. 1883–1985: В 2 кн. К., 1985.

*Әд.:* Хамматов Ш.Х. Казанская организация большевиков в годы первой русской революции. К., 1955; Тарасов А.А. Казанские большевики в период подготовки и проведения Октябрьской революции. К., 1956; Климов И.М., Саркин В.Г. Татарская партийная организация в восстановительный период (1921–1925 гг.). К., 1961; Нафигов Р.И. Казанская социал-демократическая организация в 1907–1914 гг. К., 1962; Очерки истории партийной организации Татарии. К., 1973. *Л.М.Айнетдинова.*

**«СОВЕ́ТСКАЯ ТАТА́РИЯ»**, газета; к. «*Республика Татарстан*».

**«СОВЕ́ТСКИЙ ЭСПЕРАНТИ́СТ»** («Совет эсперантчысы»), журнал. ТАССР Совет эсперантчылары берлеге органы. 1922–26 елларда Казанда рус телендә нәшер ителә.

**«СОВЕ́ТЫ ТАТАРСТА́НА»**, журнал; к. «*Татарстан Советлары*».

**СОВНАРКО́М**, к. *Халык Комиссарлары Советы.*

**СОВНАРХО́З**, к. *Халык Хуҗалыгы Советы.*

**«СОВРАБО́ТНИК»**, иҗтимагый-сәяси газета. ТАССР совет органнары хезмәткәрләре берлеге органы. 1923 елның февраленнән 1924 нең июленә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә. Татарстанның Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советлары һәм аларның башкарма органнары эшчәнлеге яктыртыла.

*Әд.:* Фасахов К.М. С жизнью в ногу (Периодическая печать Татарии в восстановительный период). К., 1979.

**СОВХО́З** (совет хуҗалыгы), дәүләт а.х. пр-тиесе. Җиргә һәм башка җитештерү чараларына дәүләт милке булуга нигезләнә, тулысынча хуҗалык исәбендә эшли, үзенең уставы, мөстәкыйль балансы һәм юридик зат хокуклары була. Татарстан терр-ясендә С.лар 1918 елдан төзелә башлый. Аларны оештыруның идеологы — В.И.Ленин, ул алпавытлардан тартып алынган биләмәләр җирлегендә эре үрнәк соц. дәүләт хуҗалыклары төзү зарурлыгын нигезли. 1919 да С.ның бурычлары билгеләнгән «Социалистик җир төзү һәм социалистик җир эшкәртүгә күчү чаралары турында нигезләмә» эшләнә. 1922 гә илдә 4316, ш.и. Татарстанда 100 С. оештырыла. ТАССР Халык Комиссарлары Советының 1922 ел 13 июнь карары б-н Совхозтрест оештырыла: 100 С.дан нибары 13 е трестка керә, башкалары ТАССР Җир эшләре халык комис-тына, төрле учреждение һәм оешмаларга бирелә. Әмма С.ларны трестлаштыру аларның икътисади хәлен сизелерлек яхшыртмый, трестлар барлык хуҗалыкларны да колачлап җитәкчелек итә алмыйлар. 1928 дә респ-када 13 С., 1934 нең 1 гыйнварына 47 С. исәпләнә.

ВКП(б) ҮК 1928 нең апрелендә булган С.ларны киңәйтү һәм ныгыту, яңаларын —

бөртекле игенчелек С.ларын оештыру һәм үстерү турында карар кабул итә. Тулысынча механикалаштырылган игенчелек С.ларыннан Ростов өлкәсенең Сал даласындагы «Гигант» С.ы һәм ТАССРның Актаныш р-ны Киров исем. С. беренчеләрдән була.

А.х. продуктлары җитештерү һәм игенчелек культурасын үстерүдә С.лар әйдәп баручы ролен үти. Оешкан көннәреннән үк аларның крәстияннәр өчен иҗтимагый күмәк а.х. җитештерүе мәктәбе булуы күздә тотыла. С.лар алдынгы технологияләр кулланалар, иң яңа техник чаралар б-н беренче чиратта тәэмин ителәләр, югары уңыш бирә торган а.х. культуралары орлыгын җитештерүдә, нәселле терлек үрчетүдә специальләшәләр, чирәм һәм яткын җирләрне үзләштерү (1954 тән), кыска гына вакыт эчендә Себердә, Идел буенда һәм Уралда яңа игенчелек С.лары оешу, С. төзелешенең алга таба үсеше тулаем а.х. продукциясе җитештерүдә дәүләт хуҗалыкларының өлеше артуга китерә. ТАССРда С. җитештерүенең икътисади нәтиҗәлелеге 8 нче бишьеллыкта (1966–70) шактый югары була. А.х. продукциясен җитештерү һәм әзерләүне арттырудагы уңышлары һәм 8 нче бишьеллык бурычларын вакытыннан алда үтәгәне өчен Аксубай р-ны «МЮД» С.ы — Октябрь Революциясе ордены, Биектау р-ны «Бөреле» С.ы Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. 1960–70 тә С.ларның табышлылыгы 40,9% (колхозларныкы — 18,2%) була. 1975 тә респ-када а.х. продукциясе җитештерүдә С.ларның өлеше: бөртекле ашлыклар — 41%, яшелчә — 38%, сөт — 28%, йомырка — 48%, йон 44% тәшкил итә. Аеруча җәнлек үрчетү, терлек симертү, җиләк-җимеш-яшелчә үстерү һ.б.да специальләшкән С.лар яхшы табыш ала.

1975 тә СССР А.х. министрлыгының барлык С.лары тулы хуҗалык исәбенә күчә, бу исә аларга җитештерүне алга таба үстерүгә киң мөмкинлекләр ача. Шуннан соңгы елларда аларда сыйфат һәм сан үсеше күзәтелә. 1985 тә ТАССРда 278 С. була, товарлыклы продукция җитештерүдә аларның өлеше 49%, а.х. продуктларын дәүләтнең сатып алуында: бөртекле ашлык — 50%, бәрәңге — 37%, яшелчә — 61%, терлек һәм кош — 54%, сөт — 44%, йомырка — 90%, йон — 47% тәшкил итә (С.лар үсешенең төп күрсәткечләре таблицада китерелә).

Куәтле матди-техник базалары булган С.лар сазлыкларны киптерү, җирләрне сугару һәм аларның уңдырышлылыгын күтәрү буенча зур мелиорация эшләре алып баралар. Минераль ашламалар, үсемлекләрне саклауның химик чаралары, химик азык өстәмәләре һ.б. б-н тәэмин ителү арта.

Специальләшкән эре С.ларда терлекчелек комплекслары төзелә, аларда, азыкны азрак (20–30% ка) сарыф итеп һәм кимрәк (2–3 тапкыр) көч куеп, күбрәк продукция җитештерелә. С.ларда җитештерүнең специальләшүе тирәнәю хуҗалыкара җитештерү кооперациясе үсеше б-н бара, нәтиҗәдә, иҗтимагый җитештерүнең яңа формалары — эре хуҗалыкара пр-тиеләр, ЖБ, агрофирмалар барлыкка килә.

С.ларда — төп игенчелек эшләре (сөрү, чәчү, урып-җыю); терлекчелектә сыерларны саву, эчерү, сарык йоны алу һ.б. эшләр механикалаштырыла. 1986 да бер С.га күчереп исәпләгәндә 4,3 мең *га* файдаланудагы а.х. җирләре, 3,2 мең *га* чәчүлек мәйданнар, 1293 баш мөгезле эре терлек (ш.и. 385 сыер), 929 дуңгыз, 33 трактор, 14 комбайн һәм 2,7 млн. сумлык тулай продукция туры килә.

С.ның табышлылыгы үсү җитештерүгә, социаль-мәдәни төзелешкә, эшчеләрнең матди-мәдәни тормыш дәрәҗәсен яхшыртуга капитал салуларны арттырырга мөмкинлек бирә. С.ларның үз интеллигенциясе формалаша. Аларның кадрлар үсешенә йогынтысы зур була. С.лардагы югары һәм махсус урта белемле белгечләр саны тулаем респ-ка буенча 1957 елдагы 1000 кешедән 1985 тә 6862 кешегә, ш.и. баш белгеч-агрономнар, инженер, зоотехник, вет. табибләре 792 дән 1270 кешегә җитә. Механизаторлар саны арта (1960 та — 1,6 мең кеше, 1970 тә — 11,5 мең, 1986 да 19,9 мең кеше). С.ларда 1938 дә — 16,6 мең кеше, 1990 да — 91,8 мең, 1997 дә 40,2 мең кеше эшли.

Совет хакимияте елларында С.ларны берләштереп яки бүлгәләп торалар, *колхозларның* бер өлеше С.ларга әверелә, 1990 елларда С.лар хуҗалык итүнең күмәк пр-тие, кооператив, АҖ һ.б. кебек башка формаларына күчә. ТР-да 1993 тә — 340, 1995 тә — 249, 1997 дә — 158, 1999 да — 99, 2009 да 1 С. исәпләнә (Кушымталарда 1 нче табл. кара).

*Әд.:* Зиятдинов Ф.С. Ресурсный потенциал АПК: анализ, оценка, эффективное использование. К., 2002; Шайдуллин Р.В. Крестьянство Татарстана: Экономический и общественно-политический аспекты (1920–1929 гг.). К., 2004; Сельское хозяйство Республики Татарстан: Стат. сб. К., 2008.


*Ф.С.Зыятдинов, Р.А.Борһанова.*

**СОВХОЗНЫ́Ң ГӘЙТӘ́Н БҮЛЕКЧӘСЕ́** посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 5 кеше (чуашлар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән Чистай кантоны Чулпан волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1926 да — 27, 1989 да — 21, 2002 дә — 26 кеше.

**СӨ́ЗИНОВ** Алексей Станиславович (31.12.1963, Казан), инфекционист, мед. фән. д-ры (2004), ТР ФА мөхбир әгъзасы (2013), ТРның атказ. сәламәтлек саклау хезмәткәре (2013). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1987), шунда ук йогышлы авырулар кафедрасында эшли. 1993 елдан Казан мед. ун-тының Чаллы ф-лы директоры. 1996 дан Казан мед. ун-тында (проректор), бер үк вакытта йогышлы авырулар кафедрасында, 2003 тән биомед. этикасы, мед. хокукы каф. мөдире, проф. (2005), 2009 дан ректор. Хезмәтләре йогышлы авыруларның (грипп, гепатит) барышын өйрәнүгә, Казанда мед. тарихына һәм мед. тарихын укыту методикасына карый. Уйлап табуга 4 патенты бар. БДБ илләренең этика ком-тлары форумы (2007 дән) һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы этика ком-ты (2003 тән) рәисе. Трның фән һәм техника өлкәсендә дәүләт бүләге лауреаты (2012), ТР Дәүләт Советы депутаты (2014 тән). Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Пересинусоидальные клетки ИТО в эмбриональном гистогенезе и регенерации печени человека // Рос. журн. гастроэнтерологии и гепатологии, колопроктологии. 1999. Т. 9, № 1 (автордаш); Хрестоматия по курсу биомедицинской этики. К., 2006 (автордаш); Хронические вирусные гепатиты B, C и D. Руководство для врачей. М., 2011 (автордаш).

*Әд.:* Казанский государственный медицинский университет (1804–2004): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.



В.Ю. Соймонов.

**СОЙМО́НОВ** Владимир Юрьевич (13.9.1773 — 20.8.1825, Мәскәү), дәүләт эшлеклесе, геолог, сенатор (1806), яшерен советник (1806). Дворяннар катлавыннан. Тау уч-щесен тәмамлый (С.-Петербург, 1790). 1793–97 елларда Барнаул з-ды (Томск губернасы) б-н идарә итә. 1797–1806 да (бүленеп) Берг-коллегиядә, вице-президент (1800–02). 1802–04 тә Финанс министрлыгы департаментында. 1806–22 дә Мәскәү берг-инспекторы, ш.у. Сенатның 7 нче департаментында хезмәттә. 1822 дән Казан генерал-губернаторы. Бер үк вакытта, 1823–24 тә, Екатеринбург махсус вакытлы тау комиссиясе рәисе. С. вазифаи җинаятьләр б-н көрәшә, Казан губернасында административ, мәхкәмә һәм сословиеле органнарның эшчәнлеген күзәтә. Аның күзәтчелегендә дворяннар һәм шәһәр сайлаулары уздырыла, губерна һәм өяз учреждениеләренә кадрлар сайлана. С. заманында полиция эшчәнлеге, губерна терр-ясендә тимер юллар төзү җайга салына. 1823 тән К.Ф.*Фукс* б-н бергә Идел буе һәм Уралда файдалы казылмалар эзләү б-н шөгыльләнә. Дәүләт идарәсе һәм тау эше буенча хезмәтләр авторы.

Хезм.: Из бумаг В.Ю.Соймонова // Горный журнал. 1894. Февр.

*Әд.:* Кулибин С.Н. Владимир Юрьевич Соймонов // Горный журнал. 1894. Февр.; Лобанов-Ростовский А.Б. Русская родословная книга. СПб., 1895. Т. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**СОКМА́Н** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 50 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чаж елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 116 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Чаж, Починок По речке Чаж исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет,

мәдрәсә, почта станциясе була; базар эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1897 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Зур Кибә волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1762 дә — 136, 1859 да — 443, 1887 дә — 608, 1905 тә — 741, 1920 дә — 956, 1926 да — 1067, 1938 дә — 847, 1958 дә — 381, 1970 тә — 281, 1989 да — 148, 2002 дә — 120 кеше.

*Әд.:* Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**СО́КОВА** Антонина Фёдоровна (24.6.1934, Алексеев р-ны Алексеев а.), галим зоотехник, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. зоотехнигы (1984), РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1989). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), Тува АССРның «Великий Урал» с-зында баш зоотехник булып эшли, Чистай җәнлек с-зында зоотехник (1960 тан), Красноярск төбәгенең «Усинский» терлек үрчетү с-зында зоотехник (1965 тән), «Матюшинский» җәнлек с-зында баш зоотехник (1970 тән), директор (1979 дан), «Матюшино» АҖдә директор (Лаеш р-нының Орёл пос., 1994–98). С. җитәкчелегендә бу хуҗалыкта сугым пункты, 450 *т* сыешлы ике суыткыч, хуҗалык хезмәткәрләре өчен 140 тан артык фатир, мәдәният сарае һ.б. җитештерү объектлары, социаль-мәдәният һәм көнкүреш биналары төзелә, асфальт юл салына. Орёл посёлогында барлык йортларга, җитештерү биналарына газ кертелә. Чәшке һәм куян үрчетүгә өстәп, көмеш-кара төлке, ак төлке, көзән үрчетү оештырыла. 1979–97 дә бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан — 6,3 *ц* дан 31 *ц* га, тулай продукция бәясе (чагыштырма бәяләрдә) 1,7 тапкырга арта. Җәнлек тиресе сатуның еллык дәрәҗәсе 127,5 мең данә, табышлылык дәрәҗәсе 95% ка җитә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын, көмеш, бронза медальләре, СССР, ТР ЮС Президиумнарының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

**СОКОЛЕ́НКО** Алексей Лукич (8.3.1926, Украина ССР, Днепропетровск өлкәсенең Пятихатки р-ны Жёлтая Река руднигы), танк гаскәрләре генерал-майоры (1970). Төньяк Кавказ танк уч-щесен (1948), Бронетанк гаскәрләре хәрби академиясен (Мәскәү, 1960), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академия каршындагы Югары академия курсларын (Мәскәү, 1971) тәмамлый. 1943 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, Волхов һәм Ленинград НКВДсындагы 105 нче чик сакчылары полкы курсанты-чик сакчысы, 2 нче һәм 1 нче Украина фронтларының 1347 нче укчы полкындагы 225 нче укчы дивизиясендә взвод командиры ярдәмчесе. 1948–53 тә Төньяк Кавказ Хәрби округының 30 нчы аерым бригадасындагы 218 нче аерым үзйөрешле танк батальоны танк взводы, танк ротасы командиры. 1953 тә Дон Хәрби округында 295 нче укчы дивизиясенең 218 нче аерым үзйөрешле батальонында рота командиры. 1954–57 дә Германиядә 3 нче армиянең совет гаскәрләре төркеме 18 нче мотоукчы дивизиясендә: 1954 тә танк полкында рота командиры, 1954–57 дә 120 нче аерым разведка батальонында рота командиры, 1957 дә 60 нчы мотоукчы полкында танк батальоны командиры урынбасары. 1960–69 да Карпат буе Хәрби округында: 1960–62 дә 30 нчы гв. танк дивизиясендә 276 нчы танк полкы батальоны командиры, 1963–69 да 23 нче танк дивизиясендә 135 нче танк полкы командиры урынбасары, командир. 1969–75 тә Үзәк төркем гаскәрләренең 31 нче танк дивизиясе командиры. 1975–84 тә ТАССРның ЮС Президиумы исем. Казан югары танк командирлары уч-щесе башлыгы. 1984 нең июленнән запаста, Мәскәүдә яши. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**СОКО́ЛИНА** Флюрә Мөхәммәтгали кызы (16.8.1936, Оренбург ш.), паразитолог, биол. фән. д-ры (2004), проф. (2006). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1965), Казан мед. ин-тында эшли. 1970 елдан Казан ун-тында. Хезмәтләре паразитология, трематодология, малакологиягә карый. С., бавыр имгеч (Fasciola hepatica) мирацидийларына (личинкаларына) һәм аның арадаш хуҗасына (Limnaea Truncatula) электрон, фазалы-каршылыклы, яктылык һәм күчереп төшерү микроскопияләре кулланып, популяция, организм, тукыма һәм күзәнәк дәрәҗәсендә морфофункциональ һәм экология-фауна тикшеренүләре үткәрә. Тикшеренү нәтиҗәләре кеше һәм хайваннар бавыры фасциолёзын дәвалау өчен препаратлар синтезлауның нигезен тәшкил итә. Вьетнамда югары белем бирү реформасы буенча Халыкара проектта катнаша (1989). «Россия фәне абруен ныгыткан өчен» медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: Формирование, ультраморфология, биология и экология мирацидия Fasciola hepatica L., 1758. К., 2003; Ультраморфологический уровень познания организации мирацидия Fasciola hepatica L., 1758. К., 2007.

**СОКО́ЛКА** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 20 *км* төньяктарак, Зәй елгасы буенда. 2010 елда 491 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.да чиркәү, чиркәү-приход һәм земство мәктәпләре, 3 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4117 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Микулин волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 1052, 1889 да — 1160, 1897 дә — 1779, 1910 да — 1961, 1920 дә — 1797, 1926 да — 1517, 1938 дә — 941, 1949 да — 699, 1958 дә — 692, 1970 тә — 721, 1979 да — 625, 1989 да — 440, 2002 дә — 489 кеше.

**СОКО́ЛКА** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 27 *км* көньяктарак, Кама елгасы ярындагы пристань. 2010 елда 607 кеше (руслар) яши. Такта яру һәм кирпеч з-ды. Урта мәктәп, клуб. Чиркәү. 1680 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Сокольи Горы исеме б-н билгеле. 1690 еллардан халкы Мәскәү Дон Богородица монастырена карый, 1763 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, елга промыселы, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Введение чиркәве (1753 тә төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), телефон бүлекчәсе, 2 җил тегермәне, пароход пристане, 2 сыраханә, чәйханә, 1 казна шәраб һәм 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1564 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Троица-Сәкинәс волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 182 ир-ат; 1859 да — 975, 1897 дә — 1220, 1908 дә — 1363, 1920 дә — 1459, 1926 да — 1293, 1938 дә — 1772, 1949 да — 2526, 1958 дә — 1783, 1970 тә — 2693, 1979 да — 1898, 1989 да — 1288, 2002 дә — 819 кеше.

**СОКО́ЛКА УРМАНЧЫЛЫГЫ́** посёлогы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 30 *км* көньяктарак, Кама елгасы буенда. 2010 елда 42 кеше (руслар, татарлар) яши. Урман хуҗалыгы. 1940 ларда нигез салына. Халык саны: 1989 да — 108, 2002 дә — 64 кеше.

**«СОКО́ЛКА УРМАНЫ́»**, ландшафтлы табигать истәлеге, Мамадыш р-ны терр-ясендә, Соколка авылыннан көньяк-көнбатыштарак. Урман массивы Каманың уң ярында Вятка тамагыннан түбәндәрәк (Мамадыш урманчылыгының Соколка урманчылыгы участогы). 1984 елда билгеләнә. Мәйданы 3852 *га*. Соколка таулары (абс. биеклекләр 140–160 *м*) дип аталучы баскычсыман субүләр платоны били. Тайга һәм киң яфраклы урманнар өчен хас бай куаклык һәм үлән капламлы нарат (табигый һәм утыртылма) һәм катнаш урманнар; имәнлекләр һәм каенлыклар очрыйлар. Яр буе участокларын кара тополь һәм ак талның өлгергән утыртмалары, тугай болыннары һәм күлләре били. Соколка тауларыннан Камага, Кама аръягына һәм киң Вятка-Кама тугаена гаҗәеп матур күренеш ачыла. ТРның Кызыл китабына кертелгән төрләрдән үләт бөркете, борындык очрый.

*Ф.Г.Борһанов.*



«Соколка урманы» ландшафтлы табигать истәлеге.

**СОКОЛО́В** Александр Васильевич (20.8.1825, Казан губ., Ядрин өязе Шемердяково а. — 3.12.1875, Казан), хокук белгече, хокук белеме магистры (1853), хакыйкый статский советник (1872). Руханилар катлавыннан. Казан руханилар семинариясен (1845), Казан ун-тын (1849) тәмамлый. 1849–53 елларда Дерпт ун-тында проф. стипендианты. 1854–60 та Рим законнары каф. адъюнкты, 1860–61 дә экстраординар профессоры, 1861–62 дә Казан ун-тының граждандлык законнары каф. экстраординар профессоры, 1862 дән ординар профессоры. Хезмәте сәүдә хокукы өлкәсенә карый. Казан юридик җәмгыяте Уставы проекты авторы.

Х е з м.: Der Kaufcontract nach russischem Reichsrechte. Дерпт, 1853.

*Әд.:* А.В.Соколов: Некролог // Уч. зап. Казан. ун-та. 1876. Т. 12, вып. 1; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**СОКОЛО́В** Борис Сергеевич (18.7.1942, Казан), төзелеш механикасы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1990), проф. (1991), Россия архит-ра һәм төзелеш фәннәре академиясенең мөхбир әгъзасы (1999), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2001). 1964 елда Казан төзүче инженерлар ин-тын (хәзер Казан архит-ра-төзелеш ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, тимер-бетон һәм таш конструкцияләр каф. мөдире (1989 дан). Хезмәтләре анизотроп материалларның кысуга каршылыгы нигезләрен тикшерүгә карый. С. кысканда бетонның физик җимерелүе моделен тәкъдим итә һәм шуның б-н өзелү, шуышу һәм батыру каршылыкларын узу процессын сурәтли. Тикшеренү нәтиҗәләре конструкцияләрнең материал чыгымын киметү, бина һәм корылмаларның ышанычлылыгын арттыру мөмкинлеге бирә. Торак йортлар, дөньяви һәм дини корылмаларны үзгәртеп кору буенча 100 дән артык проект эшли. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000).

Х е з м.: Теоретические основы сопротивления бетона и железобетона при сжатии // Изв. вузов. Строительство. 1993. № 9; Прочность объёмных элементов из керамзитбетона при местном действии нагрузки // Изв. вузов. Строительство. 1999. № 5 (автордаш); Физическая модель разрушения каменных кладок при сжатии // Изв. вузов. Строительство. 2002. № 9; Состояние и перспективы развития теоретических основ сопротивления анизотропных материалов (бетона и каменных кладок) сжатию // Вестн. отд-ния строит. наук. 2007. Вып. 11.

**СОКОЛО́В** Владимир Константинович (25.3.1871, Вологда губ., Грязовецкий өязе Николай Становский а. — 17.3.1921, Казан), хокук белгече, кануни хокук д-ры (1912), статский советник (1913). Руханилар катлавыннан. Казан руханилар академиясен (1895), Казан ун-тын тәмамлый (1899). 1899–1901 елларда Казан ун-тының проф. стипендиаты, 1902–13 тә экстраординар проф., 1913–19 да чиркәү хокукы кафедрасының ординар профессоры, 1919 дан социол. каф. профессоры. Бер үк вакытта Югары хатын-кызлар курсларында укыта (Казан). 1917–18 дә Рус Православие чиркәвенең Поместный соборында катнаша. С.ның «Гамәлдәге хокук буенча Германиядә диннең дәүләти хәле» («Государственное положение религии в Германии по действующему праву», 1899), «XIX йөзнең икенче яртысында Германиядә католик чиркәве һәм дәүләт» («Католическая церковь и государство в Германии во второй половине XIX столетия», 1912) хезмәтләре Германиядә диннең «мәдәният өчен көрәш» («культуркампф») дәверендәге дәүләти хәленә багышлана. Россиядә дин иреге мәсьәләләре буенча хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Свобода совести и веротерпимость: Ист.-критический очерк. СПб., 1905; Наши епископы и самодержавие. СПб., 1906.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Биобиблиогр. словарь профессоров и преподавателей Казанского университета 1905–1917. К., 1986; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**СОКОЛО́В** Владимир Михайлович (7.6.1884, Тверь ш. — 3.2.1937, Казан), фармаколог, мед. фән. д-ры (1935). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1911), шунда ук күз авырулары клиникасында эшли, аннары Тәтеш земствосында участок табибе. 1914 елдан кабат Казан ун-тында: фармакол. (рецептура һәм токсикология б-н бергә) кафедрасында прозектор ярдәмчесе, 1918 дән фармакол. кабинеты мөдире, 1921 дән укыту эшендә, 1925–30 да проф. (1915 тә Петроградта акад. И.П.Павлов һәм проф. Н.П.Кравков лаб-ясендә стажировка уза). Бер үк вакытта, 1917–23 тә, Казан губ. земстволының фельдшерлар мәктәбендә, 1930–33 тә Шәрекъ пед. ин-тында укыта. 1930–37 дә Казан мед. ин-тының дәвалау ф-ты деканы. Фәнни тикшеренүләре дару матдәләренең үзара каршылыгын һәм бер-берсен көчәйтүләрен, табигый шартларның агулар тәэсиренә йогынтысын, калкансыман бизнең секретор нервларын, уймак чәчәкнең йөрәккә һәм кан басымына тәэсирен өйрәнүгә карый.

Х е з м.: К вопросу о секреторных нервах щитовидной железы // Журн. эксперим. биохимии и медицины. 1923. № 41; О зависимости между величиной дозы и силой действия ядов // Журн. эксперим. биологии и медицины. 1925. № 29; К вопросу о синергизме адреналина и тиреоидина // Казан. мед. журн. 1926. № 10.

**СОКОЛО́В** Дмитрий Иванович (1788, С.-Петербург — 19.11.1852, шунда ук), геолог, РФА академигы (1839), Петербург ФАнең шәрәфле әгъзасы (1841). 1805 елда Тау эшләре кадет корпусын тәмамлаганнан соң (С.-Петербург), шунда ук укыта (1841 гә кадәр). Бер үк вакытта (1822–44) минерал. һәм геогнозия каф. профессоры, 1844 тән Петербург ун-тының тел һәм тел белеме бүлеге башлыгы. Хезмәтләре геологиягә карый. С. Россиянең төрле районнарында, ш.и. Казан губернасы терр-ясендә геол. тикшеренүләр үткәрә. Кама буе һәм Идел аръягындагы кызыл төстәге утырмаларны геол. система буларак бүлеп чыгара (1839), соңрак (1841) Р.Мурчисон аларны Пермь системасы дип атый. Рус телендә беренче минералогия һәм геология дәреслекләре — «Минералогия буенча куллан-ма...» («Руководство к минералогии...», 1–2 кис., СПб., 1832), «Геогнозия курсы» («Курс геогнозии», 1–3 кис., СПб., 1839) авторы. Өч тапкыр Петербург ФАнең Демидов бүләгенә лаек була (1832, 1839, 1842).


Л.М.Соколов.

**СОКОЛО́В** Евгений Михайлович (14.5.1938, Смоленск өлкәсенең Краснинск р-ны Кузино а. — 4.4.2003, Лениногорск ш.), тау инженеры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002), РФнең атказ. төзүчесе (1993). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1972). 1961–64 елларда «Лениногорскнефть» нефть промыселы идарәсендә слесарь-механик, скважиналар тикшерү операторы, 1964–2003 тә «Татнефть» АҖнең «Иркеннефть» НГДУында: мастер, скважиналарны тикшерү буенча өлкән инженер, башлык урынбасары, өлкән геолог, пласт басымының район инженер-технол. хезмәте башлыгы, нефть һәм газ чыгару буенча технол. бүлек башлыгы, башлык урынбасары. Дәүләт бүләге экологик чиста технологияләрне эшләгәне һәм гамәлгә керткәне, тузган, вакланган шиннарны утильләштерү өчен модульле җайланмалар комплексын сәнәгатьтә җитештерүне оештырганы өчен бирелә. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә.

**СОКОЛО́В** Леонид Михайлович (28.4.1908, Казан губ., Казан өязе Пимәр пос. — 12.3.1981, Смоленск ш.), Сов. Союзы Герое (27.6.1945), гв. полковнигы. Очу эшен Казан аэроклубында үзләштерә (1937), авиация звеносы командирлары курсында укый (1942). Казан аэроклубында моторист, очучы-инструктор, звено командиры була. 1932–33 елларда һәм 1942 нең маеннан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 107 нче гв. истребительләр авиация полкының (2 нче авиация штурм корпусының 11 нче гв. истребительләр авиация дивизиясе) эскадрилья командиры. 1945 елның маена 230 сугышчан очыш ясый, 62 һава сугышында дошманның шәхсән — 17, төркем б-н 6 самолётын бәреп төшерә. Сугыштан соң СССР Хәрби-һава көчләрендә хезмәтен дәвам итә. 1958 дән запаста. Смоленск шәһәрендә яши һәм эшли. Ленин ордены, өч Кызыл Байрак, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Смоленскида С. яшәгән йортка мемориаль такта куелган.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СОКОЛО́В** Леонид Петрович (16.4.1903, Түбән Новгород ш. — 18.1.1984), инженер-полковник, Казан авиация з-ды директоры (1949–53). Хезмәт эшчәнлеген «Кызыл Сормово» з-дында (Горький ш.) слесарь буларак башлый. 1924–30 елларда комсомол эшендә. Н.Е.Жуковский исем. Хәрби-һава инженерлары академиясен тәмамлаганнан соң (1936), илдәге самолётлар төзү з-дларында эшли. 1953–57 дә СССР Авиация сәнәгате министрлыгының 10 нчы Баш идарәсе башлыгы. 1957–62 дә СССР Авиация сәнәгате министрлыгының КХРдагы вәкиле. С. җитәкчелегендә Казан авиация з-дында ерак арага очучы авыр Ту-4 бомбардировщигын эшләп чыгару үзләштерелә һәм камилләштерелә, ракеталар б-н коралланган ерак арага очучы Ту-16 бомбардировщигын эшләп чыгару җайга салына, 2 нче күтәрелү-төшү полосасы, самолётлар өчен бетон мәйданчык, очыш-сынау станциясе һ.б. файдалануга тапшырыла. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1949). Өч Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» һ.б. орденнар, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Завод стратегического назначения. К., 2002.

*Д.С.Фәхретдинов.*

**СОКОЛО́В** Михаил Павлович (16.10.1945, Оренбург өлкәсенең Яңа Орск р-ны Таналык а.), химик-технолог, химия фән. д-ры (1980), проф. (1983). 1969 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1980 нән Кама инженерлар-икътисад академиясендә химия һәм экология каф. мөдире. Хезмәтләре фосфорорганик кушылмалар химиясенә карый. С. фосфорилланган карбониль кушылмалар синтезлау алымнарын эшли, аларның таутомериясен һәм реакциягә сәләтен өйрәнә. Триад һәм пентад системаларны табу юлларын тәкъдим итә. Биологик актив фосфорорганик кушылмалар синтезлый. «Түбәнкаманефтехим» АҖнең лапрол җитештерү калдыкларыннан ябыштыру һәм майлау композицияләре таба. Фосфорилланган альдегидлар һәм иминнар таутомериясе өлкәсендәге тикшеренүләре өчен Бөтенсоюз химия җәмгыятенең Д.И.Менделеев исем. бүләгенә лаек була (1973). Хезмәтләре экологиягә карый. Уйлап табуга 15 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2000).

Х е з м.: Фосфорилированные альдегиды // Успехи химии. 1972. Т. 42 (автордаш); Фосфорилированные нитрозоенолы // Журн. общей химии. 1977. Т. 47 (автордаш); Исследование таутомерии фосфорилированных β-дикарбонильных соединений, производных ацетоуксусного эфира и ацетилацетона // Журн. общей химии. 1978. Т. 48 (автордаш).

*Әд.:* Энциклопедия города Набережные Челны. К., 2007.

**СОКОЛО́В** Михаил Сергеевич (26.10.1914, Владимир губ., Нерехта өязе Рождествено а. — 18.11.1966, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Бөтенсоюз читтән торып белем бирү икътисад ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1956). Казандагы Орджоникидзе исем. 124 нче з-дта: 1935–38 елларда конструктор, бригада башлыгы, бүлек башлыгы урынбасары, 1938–39 да ВЛКСМ ком-ты секретаре, 1939–41 дә өлкән диспетчер. 22 нче Казан авиация з-дында: 1941–43 тә цех башлыгы урынбасары, 1943–45 тә башлыгы, 1945–46 да партком секретаре урынбасары, 1946–49 да ВКП(б) ҮК парторгы, 1954–58 дә директор ярдәмчесе. 1949–54 тә Иркутскидагы 39 нчы з-д директоры ярдәмчесе — ф-л башлыгы. 1958–60 та хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары. 1960 тан ТАССР МС каршындагы Дәүләт план комиссиясе рәисе. 1963 тән ТАССР ЮС депутаты. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**СОКОЛО́В** Николай Владимирович (22.2.1882, Казан губ., Лаеш өязе Шуран а. — 22.9.1963, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1924), проф. (1926), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән. эшлеклесе (1939, 1940). Проф. Н.А.Геркен, акад. А.В.Вишневский шәкерте. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1908), шунда ук факультет хирургиясе клиникасында эшли. 1913 елдан Вятка губернасының Малмыж земство хастаханәсендә хирургия бүлеге мөдире. 1914–17 дә фронт госпитальләрендә. 1918–21 дә Кызыл Армия госпитальләрендә, бер үк вакытта Казандагы Адмиралтейство хастаханәсенең хирургия бүлеге мөдире. 1920 дән Казан ун-тының оператив хирургия кафедрасында прозектор ярдәмчесе, 1921–26 да госпиталь хирургиясе клиникасында проф. А.В.Вишневский карамагында. 1926–40, 1942–50 дә Казан ГИДУВының оператив хирургия каф. мөдире. Бер үк вакытта Казан мед. ин-тының оператив хирургия (1931–33), гомуми хирургия (1933–35), госпиталь хирургиясе (1935–63) кафедралары мөдире, дәвалау ф-ты деканы (1938–42), директор урынбасары (1945–46). Хезмәтләре топографик анатомиягә, иммунологиягә, хәрби-кыр һәм кичектергесез хирургиягә, кискен хирургик ялкынсыну авыруларын, септик халәтне, үлекле перитонитларны, эчәккә тоташкан эренле тирән яраларны дәвалауга карый. А.В.Вишневский ысуллары тарафдары (аерым урынга инфильтратив анестезия, новокаин блокадасы). ТАССРның Респ-ка хирурглар җәмгыяте рәисе (1935 тән). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Краткое руководство по хирургической анатомии для студентов и врачей. К., 1935; Неотложная хирургия. К., 1947 (автордаш); Хирургический сепсис. К., 1957.

*Әд.:* Профессор Николай Владимирович Соколов // Казан. мед. журн. 1963. № 6.

**СОКОЛО́В** Пётр Алексеевич (1800 тирәсе, Харьков ш. — 1864, Екатеринбург ш.), актёр, антрепренёр. Сәхнә эшчәнлеген О.И.Калиновский труппасында башлап җибәрә, 1827 ел тирәсендә Воронеж шәһәрендә, соңрак Тамбов, Саратов, Сембер шәһәрләрендә үзенең шәхси антрепризасын оештыра. 1833 нең язынннан 1842 нең язына кадәр Казанда труппа б-н җитәкчелек итә, аның составында «ирекле» актёрлар б-н беррәттән крепостной, ягъни «оброк түләүче» актёрлар да була. Соңрак Мәскәүдәге Кече театр актёрлары гаиләсенә нигез салган П.М.Садовский үзенең эшчәнлеген Казанда С. труппасында башлап җибәрә. Рус театр провинциясенең алдынгы эшлеклеләреннән берсе буларак, ул репертуарга да, актёрларның проф. әзерлегенә дә җитди игътибар бирә; шул максаттан Мәскәү һәм Петербург театрларының олпат сәхнә осталарын гастрольләргә чакыра. С. антрепризасы елларында Казанда беренче тапкыр А.С.Грибоедовның «Акыллылык бәласе» («Горе от ума»), Н.В.Гогольнең «Ревизор», И.А.Крыловның «Төшемле кибет» («Модная лавка»), Д.И.Фонвизинның «Җитлекмәгән егет» («Недоросль»), Я.Б.Княжнинның «Филат туе» («Филаткина свадьба»), «Ям», «Ирләр — үз хатыннарының кияүләре» («Мужья — женихи своих жён»), А.А.Шаховскойның «Ксанф янындагы Эдип» («Эдип у Ксанфа»), «Ярымбайлар уены» («Полубарские затеи»), «Шигырь язучы казак» («Казак-стихотворец»), М.Н.Загоскинның «Богатонов, яки Провинция кешесе башкалада» («Богатонов, или Провинциал в столице»), «Үз-үзеңә сюрприз» («Сюрприз самому себе»), Ж.Б.Мольерның «Дворяннар арасындагы мещан» («Мещанин во дворянстве»), «Дон Жуан», «Скапен хәйләләре» («Плутни Скапена»), В.Дюканжның «Комарбазның хәяте» («Тридцать лет, или Жизнь игрока») пьесалары буенча спектакльләр, ш.у. Булья, Дж. Паизиелло, К.А.Кавос, А.Н.Титов оперालары куела. Труппаның Казан тамашачысын яңа муз. әсәрләр б-н таныштырган дирижёрлар Семёнов, Немвродов җитәкчелегендәге оркестры катнашуында концертлар уздырыла. 1842 дә янгын чыгу сәбәпле, театр бинасыз кала һәм С. труппасы башта Уфага, аннан соң Екатеринбургка күчеп китә.

*Әд.:* О Казанском театре // Репертуар русского театра. 1840. Кн. 8; К р у т и И. Русский театр в Казани. М., 1958; К у р о ч к и н Ю. Бабушка уральского театра. Свердловск, 1969; Театральная энциклопедия. М., 1965. Т. 4.

*Ю.А.Благов.*

**СОКОЛО́В** Сергей Николаевич (12.10.1913, Казан — 21.8.1983, Мәскәү), Сов. Союзы Герое (19.8.1944), генерал-лейтенант (1981), хәрби фән. канд. (1968). Оренбург очучылар хәрби авиация мәктәбен (1937), проф. Н.Е.Жуковский исем. Хәрби-һава инженерлар академиясен (Мәскәү, 1948), К.Е.Ворошилов исем. СССР Кораллы Көчләре Генштабы Хәрби академиясен (Мәскәү, 1955) тәмамлый. 1935 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 3 нче гв. авиация полкының сәяси эшләр буенча командир урынбасары (2 нче гв. авиация корпусының 2 нче гв. авиация дивизиясе). Өч елда (1944 нең июленә) ДБ-3 һәм Ил-4 бомбардировщиклары б-н дошман тылындагы хәрби сәнәгать объектларына 197 хәрби очыш ясый. 1964 тән К.Е.Ворошилов исем. СССР Кораллы Көчләре Генштабы Хәрби академиясендә укыта. 1974 тән отставкада, Мәскәүдә яши. Ике Ленин ордены, өч Кызыл Байрак, Александр Невский,

1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СОКОЛО́ВА** Екатерина Александровна (14.11.1911, Казан — 20.11.2013, шунда ук), пианист-ансамблист, педагог, ТАССРның атказ. артисты (1957). 1936 елда Ленинград консерваториясен фортепиано буенча (П.Серебряков классы) тәмамлый. 1943–72 дә ТАССР МС каршындагы Радио һәм телевидение дәүләт ком-тында концертмейстер, бер үк вакытта, 1936–60 та, 1 нче балалар музыка мәктәбендә, 1960–68 дә Казан пед. ин-тында укыта. Концертмейстер буларак, гаять зур репертуарны үзләштерә, әйдәп баручы музыкантлар (А.Хәйретдинов, М.Булатова, Ф.Насретдинов, З.Хисмәтуллина, И.Халитов һ.б.) б-н чыгышлар ясый. Татар музыкасын актив пропагандалаучы. Н.Җиһанов, А.Ключарёв, Р.Яхин һ.б.ның күп кенә фортепиано әсәрләрен беренче башкаручы. С. иҗатына проф. осталык, ансамбльне тою, көй стиле һәм үзенчәлеге хас. Зур концерт эшчәнлеге алып бара, яшь башкаручыларның иҗади үсешенә ярдәм итә, укыту-методик әдәбият, ноталы басмалар төзи һәм редакцияли.

*Ф.Ш.Салитова.*

**СОКОЛО́ВКА** посёлогы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 33 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 6 кеше (руслар) яши. 1950 ләрдә нигез салына. Оешкан көненнән Столбище р-нында. 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1949 да — 51, 1958 дә — 26, 1970 тә — 24, 1979 да — 75, 1989 да — 12, 2002 дә — 10 кеше.

**СОКОЛО́ВСКИЙ** Алексей Андреевич (23.6.1822, Түбән Новгород ш. — 3.11.1891, Казан), фармаколог, медицина д-ры (1851). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1845), шунда ук терапия клиникасында, 1848 елдан мәхкәмә медицинасы һәм мед. ярдәме кафедрасында эшли, 1857 дән дару матдәләре табиблеге кафедрасында экстраординар проф., бер үк вакытта фармакология (рецептура б-н) буенча укытучы, 1859 дан фармакология ординар профессоры, 1862 дән мед. ф-ты деканы. 1861–62 дә Германиядә командировкада була. 1863 тә Халык мәгарифе министрлыгы карамагында. 1864 тән Мәскәү ун-тының фармакология каф. мөдире. 1881 дә авыру сәбәпле отставкага чыга һәм Казанга кайта. Хезмәтләре нейроморфологиягә, гомуми һәм махсус фармакологиягә карый.

Х е з м.: Питательные вещества и напитки. К., 1859; О тифозной горячке // Уч. зап. Казан. ун-та. 1860. № 1.

*Әд.:* Д а г у р о в В.Г. Развитие фармакологии в Московском университете во 2-й половине XIX века // Фармакология и токсикология. 1983. Т. 46, № 1.

**СОКО́ЛЬСКАЯ** Юзефина Юзефовна (22.11.1945, Варшава, Польша), пианист-ансамблист, педагог, проф. (2001), ТРның халык артисты (1995). 1969 елда Казан консерваториясен (В.А.Столов классы) тәмам-



С.Н.Соколов.




Ю.Ю.Сокольская.

лый. 1974–76 да Воронеж сәнгать ин-тында укыта. 1968–74 тә һәм 1976 дан концертмейстерлык кафедрасында (1995 тән каф. мөдире), 1983–85 тә Казан консерваториясенең фортепиано ф-ты деканы. Концертмейстерлык һәм камера җыры классларын алып бара. Шәкертләре арасында халыкара һәм бөтенроссия конкурслары лауреатлары С.Гуляк, Е.Баландина, А.Абашев, И.Нигъмәтуллин, А.Барышникова, И.Лоренц, А.Яхина, О.Логинова, Лю Ин-Сук (Көньяк Корея) һ.б. бар. Бер үк вакытта, 1983 тән, Татар опера һәм балет театры концертмейстеры. Бөтенроссия, бөтенсоюз һәм халыкара конкурслар дипломанты (концертмейстер буларак). Концерт эшчәнлеген солист буларак алып бара.

**СОКО́ЛЬСКИЙ** посёлогы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 12 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Зәй елгасы буенда. 2010 елда 23 кеше (руслар). 20 йөз башында нигез салына. Башта Сокольский Хуторы дип атала. Оештырылган көненнән Самара губернасының Бөгелмә өязе Микулин волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1910 һәм 1920 дә — 68 әр, 1926 да — 152, 1938 дә — 115, 1949 да — 89, 1958 дә — 85, 1970 тә — 56, 1979 да — 54, 1989 да — 24, 2002 дә — 17 кеше.

**СОКО́ЛЬСКИЙ** Николай Михайлович (22.3.1900, Казан губ., Цивильск ш. — 5.12.1970, Казан), график, нәкышьче, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1944). 1923 елда Архит-ра-техник ин-тын тәмамлый. Кызыл Армиядә хезмәт иткән вакытында укуы өзелеп тора (1919–22). Ин-тның график ос-



Н.М.С о к о л ь с к и й. «Гостиный двор». «Казан Кремле» альбомыннан. Кәгазь. Төсле линогравюра. 1923. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

таханәсен җитәкли (1923–25). «Красная Татария» г-тасы (1925–45), «Чаян», «Азат хатын», «Атака» кебек Казан ж-ллары б-н хезмәттәшлек итә (1920–30 еллар). Рәссамнар берлеген, «Окна сатиры РОСТА"ны оештыруда катнаша, аларда әгъза булып тора (1936; 1941), остаханәдә чыгарылган плакатлар авторы. «*Всадник*» (1923), АХРРның Татарстан бүлеге (1925) иҗат берләшмәләре әгъзасы.

Иҗат юлын график, эстамплар, китап-журнал иллюстрацияләре, плакатлар авторы, полиграфик продукцияләр бизәүче (тышлык, титул битләре, китап исемнәре эскизлары һ.б.) буларак башлый. Басма хезмәтләр чыгаруда «Всадник» коллективы традицияләрен дәвам итә. «Казан» төсле линогравюралар альбомы (1923), «Шәһәр пейзажы» линогравюрасы (1923), «Асфальт түшәүчеләр» литография һәм офортлары (1925), «Заводта тәнәфес вакыты» офорты (1925 тирәсе); тушь



Н.М.С о к о л ь с к и й. «Яз. Соңгы кар». 1936. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

һәм карандаш техникаларында портрет, тарихи, көнкүреш һәм агитация жанрларында башкарылган станлы һәм газета рәсемнәре — респ-кадагы агымдагы вакыйгаларны, эшчеләр сыйныфы, колхозчы крәстиян тормышын яктырткан репортаж характерындагы зарисовкалар; юлбашчылар, җәмәгать эшлеклеләре һәм язучылар: В.И.Ленин (1932, 1950), С.М.Киров, М.И.Калинин (икесе дә — 1936), А.С.Пушкин (1937, 1949), М.Горький (1951) портретлары авторы. Китап графикасында С. Татгосиздатның басма әсәрләренә: И.Бабель (1920 еллар), М.Горький (1940 еллар) хикәяләренә, А.Львовның «Көлке дә, гөнаһ та» («И смех, и грех») брошюрасына (1927) иллюстрацияләр иҗат итә. Рәссам иҗатында 1920 еллар агитациясе («Бөтендөнья хезмәт ияләре 1 Майда капиталга каршы бердәм фронт төзиләр», 1923 тирәсе); «Куып җитәргә һәм узып китәргә», 1929) һәм Татгосиздатта басылган сугыш вакыты плакатлары («Канга кан! Үлемгә үлем!», 1941; «Җиңү фондына», 1944; «Берлинга!», 1945), «Окна сатиры»да трафарет техникасында кулдан чыгарылган плакатлары («Фрицның ике ялы», «Җиңү хакына барысын да бир!», «Иген үстерү», «Бүгеннән һәм мәңгегә җиребез азат», барысы да — 1941–45) аерым урын

алып тора. С. графикасына сизгер, ачык тел, төсле эре таплар һәм ачык төгәл сызыкларга тартылу хас.

Станлы нәкыше идеясенең пафослылыгы б-н аерылып тора: Ленин тематикасы, хезмәт темасы, тарихи-революцион картиналар, пейзажлар, натюрмортлар — «Яз» (1929), «Төзелештә» (1930), «Красный металлист» заводының механика цехы» (1930–34), «Кырдан соңгы олаулар» (1933), «Төнге ашлык суктыру», «В.И.Ленин 1919 елда митингта» (икесе дә — 1934), «В.И.Ленин — гимназист» (1939), «Казанда 1945 елның 9 мае — Җиңү көне» (1945–46), «Тукайның соңгы язы» (1947), «Татарстанның нефть ятмаларында» (1957), «Баранкалар б-н натюрморт» (1967), «Колхоз кыры» (1969), «Икмәк» (1970). ТатАХРР (1925 тән), төбәк — «Зур Идел» (Волгоград ш., 1967; Ульянов ш., 1969), бөтенроссия — 6 автономияле респ-ка (Казан, 1947), РСФСР рәссамнары (Мәскәү, 1949), Бөтенсоюз нәкышь, скульптура, графика сәнгать күргәзмәләре (Мәскәү, 1946), халыкара — «Китап сәнгате» (Париж, 1931), «СССРның хәзерге заман сәнгате» (Сан-Франциско, Чикаго, Филадельфия, Нью-Йорк, барысы да — 1933) күргәзмәләрендә; Татар сәнгате һәм әдәбияты декадасы көннәрендә ТАССР рәссамнары күргәзмәсендә (Мәскәү, 1957) һ.б.да катнаша. Казанда шәхси күргәзмәләре 1934 (В.А.Родионов б-н берлектә), 1943, 1965 (В.К.Тимофеев б-н берлектә), 1966 да (В.И.Куделькин б-н берлектә) уздырыла.

Әсәрләре Мәскәүдәге Иң яңа Россия тарихы музеенда (элекке Революция музее), ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, А.М.Горькийның Казандагы әдәби-мемориаль музеенда һ.б.да саклана. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Н.М.Сокольский и В.А.Родионов. К., 1934; Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

**СОКУРЫ́** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 29 *км* төньяктарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 1066 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 50%, руслар — 48%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет, чиркәү. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1550 елларда Казан архиепископы йорты карамагына бирелә, 1560 елларда — сарай, соңрак алпавыт биләмәләре булып китә. 18 йөз уртасында С.ның бер өлеше шагыйрь Г.Р.Державинның эти-әнисе утары составында була. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.да Покров чиркәве (1895 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1892 дә ачыла), җил тегермәне, тимерчелек, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2311,97 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Державин волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 87 ир-ат; 1859 да — 447, 1897 дә — 759, 1908 дә — 857, 1920 дә — 1062, 1926 да — 1299, 1949 да — 864, 1958 дә — 580, 1970 тә — 606, 1979 да — 565, 1989 да — 885, 2002 дә — 1055 кеше.

**«СОКУРЫ́»**, карабодай сорты. Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында 1977 елда Н.Н.*Петелина* һәм Ф.З.*Кадыйрова* тарафыннан чыгарыла. Тиз өлгерешле, вегетация чоры 65–70 көн. Бер вакытта өлгерә, сөрлегүгә чыдам. 1000 орлыкның авырлыгы — 30–33 *г*, кибәге 26%, тигезләнеше 98%, бөртекнең кибәксез өлеше 71%. Уртача уңышы — 1 *га* дан 21 *ц*, иң югары уңыш — 1 *га* дан 31 *ц* Чуаш АССРның Янтык сорт участогында алына. Херсон өлкәсендә «Шатиловская 5» стандартына сынау вакытында уңышка өстәмә 23% тәшкил итә, бөртегенең эрелеге буенча өстәмә — 51 *г*. Ярма сыйфаты буенча кыйммәтле сорт. 1982 дә Мордва һәм Чуаш АССРларда, Түбән өлкәсендә районлаштырыла.

*Әд.:* Районированные и перспективные сорта сельскохозяйственных культур селекции Татарского НИИ сельского хозяйства. К., 1990.

**СОЛА́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Кандыз елгасының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 33,6 *км*, ТР чикләрендә — 22 *км*. Бассейнының мәйданы 211,1 *км*$^2$. Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан ага. Елганың башы һәм югары агымы Оренбург өлкәсе терр-ясендә, тамагы Баулы р-ны Поповка авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 280 *м*, тамагыныкы — 130 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. С.ның 0,5 тән 8,5 *км* га кадәр озынлыктагы 12 кушылдыгы бар, иң зурысы — Күчелга (Кучелга) (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, якынча яртысы кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 3–5 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 179 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,649 *м*$^3$/*с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан артык. Елгада суының күләме 0,8 млн. *м*$^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**СОЛА́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Казансу елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 27,3 *км*, бассейнының мәйданы 275 *км*$^2$. Биектау р-ны терр-ясендә ага. Елга башы Олы Солабаш авылыннан 4,5 *км* төньяктарак, тамагы Тимофеевка авылыннан көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 57 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. С.ның 0,3 тән 22,5 *км* га кадәр озынлыктагы 20 кушылдыгы бар, иң зурлары: Касыйм (12,4 *км*) һәм Сая (22,5 *км*) — уң кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,57 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 146 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз



Сола елгасы. Биектау районы Усад авылы янында.

вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,45 *м*$^3$/*с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. С. бассейнында суының гомуми күләме 1,7 млн. *м*$^3$ булган 4 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**СОЛДА́Т ПИСМӘНКӘСЕ́** (Паны) авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 13 *км* төньяк-көнбатыштарак, Писмән елгасы буенда. 2010 елда 54 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — иткә терлек асрау. 1730 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Пан бистәсе исеме б-н дә билгеле. Беренче булып монда отставкадагы солдатлар һәм Яңа Кама аръягы чик буе ныгытмалары тирәсенә урнашкан яшь буын поляк шляхтичлары күчеп килә. 1838–41 дә халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Илия чиркәве (1827 дә төзелә; архит-ра истәлеге), укырга-язарга өйрәтү мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2365 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Яңа Писмән волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 574, 1889 да — 741, 1897 дә — 862, 1910 да — 829, 1920 дә — 1229, 1926 да — 971, 1938 дә — 494, 1949 да — 460, 1958 дә — 220, 1970 тә — 275, 1979 да — 181, 1989 да — 89, 2002 дә — 67 кеше.

**«СОЛДА́Т ТЕЛӘГЕ́ ҺӘМ УФА́ МӨСЕЛМА́Н ГАСКӘРИ́ ШУРАСЫНЫ́Ң ХӘБӘРЛӘРЕ́»**, атналык газета. Уфа мөселман гаскәри шурасы органы. 1917 елның 15 июненнән 14 сентябренә кадәр Уфа шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Беренче 4 саны «Уфа мөселман гаскәри шурасының хәбәрләре» исеме б-н чыга, 1917 нең 10 июленнән —

«Солдат теләге...». Мөхәррире — хәрби шураның басма, агитация һәм пропаганда бүлеге җитәкчесе Ф.Әхмәдуллин. Актив авторлары арасында — хәрби шура әгъзалары Г.Әлмөхәммәтов, И.Рәмиев, Ш.Ходайбирдин. Редакция сул эсерлар позициясендә тора (газетаның платформасы турындагы белешмәләр 3 нче санда басыла). Хәрби шура эшчәнлеге яктыртыла, мөселман губерна съездлары, мөселманнарның иҗтимагый-сәяси тормышы, аерым мөселман хәрби частьлары, милли-мәдәни автономия проблемалары, хатын-кызлар (4 нче сан) һәм башкорт (9, 10 нчы саннар) мәсьәләләре, мөселман газеталары басмалары һәм әчтәлекләре турындагы язмалар дөнья күрә. Газета битләрендә Ш.Бабич, С.Кудаш, Т.Янәби шигырьләре басыла. «*Ирек*» һәм «*Авыл халкы*» г-талары б-н берләшкәч, 1917 нең 21 сентябреннән «*Безнең юл*» исеме б-н чыга башлый.

*Әд.:* Б у л г а к о в Р.М. Уфимские национальные демократические газеты 1917 г. как источник изучения общественной жизни мусульман // Народы Урала и Поволжья накануне Октябрьской революции и осуществление ленинской национальной политики. Уфа, 1989; У с м а н о в а Д.М. Вопросы национально-государственного самоопределения на страницах татарской периодической печати (1917 – апрель 1918): Дис. ... К., 1994.

**«СОЛДА́Т ЯЛКЫНЫ́»**, газета; к. «*Тартыш*».

**СОЛДА́ТКИН** Владимир Михайлович (1.10.1945, Юдино р-ны Яңа Аракчино а.), авиация приборлары төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1995), проф. (1998), ТССРның атказ. уйлап табучысы (1991), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2002). 1970 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (бүленеп, 1962–64 тә Казан мед. аппаратуралары з-дында, 1969–70 тә Мәскәү вертолёт з-дының Казан ф-лында), Авиация сәнәгате министрлыгының үлчәү әверелдергечләре тармак фәнни-тикшеренү лаб-ясе мөдире (1981–85), приборлар һәм информацион-үлчәү системалары каф. мөдире (1999 дан). Тикшеренүләре очышларның куркынычсызлыгын тәэмин итү алымнарына һәм инструменталь чараларына карый. Очкыч аппаратларның аэродинамик почмакларындагы термоанемометрик датчикларның оригиналь конструкцияләрен тәкъдим итә, аларны исәпләү һәм проектлау алымнарын эшли, эксперименталь үрнәкләрен ясый. Гадәти булмаган хәлләрдә очышларның куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен мәгълүмати-идарә системалары кулланунның нәтиҗәлелеген бәяли. Уйлап табуга 46 авторлык таныклыгы һәм патенты бар (23е авиация сәнәгате пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Методы и средства измерения аэродинамических углов летательных аппаратов. К., 2001; Методы и средства построения бортовых информационно-управляющих систем обеспечения безопасности полёта. К., 2004; Основы проектирования измерительных приборов и систем. К., 2006 (автордаш).

**СОЛДА́ТОВ** Анатолий Петрович (12.3.1927, Новгород өлкәсенең Пилнә р-ны Княжиха ст. — 25.5.2002, Мәскәү өлкәсенең Балашиха ш.), зоотехник-селекционер, а.х. фән. д-ры (1973), проф. (1974), ВАСХНИЛның мөхбир әгъзасы (1982), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1995). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1949), 1949–52 елларда шунда ук эшли. 1952–67 дә Мәскәү вет. академиясендә. 1962–67 дә Бөтенсоюз терлекчелек фәнни-тикшеренү ин-тында. 1967–81 дә Бөтенсоюз читтән торып белем бирү а.х. ин-тында (Балашиха), аерым зоотехния каф. мөдире (1971–81), бер үк вакытта, 1979–81 дә, зоотехния ф-ты деканы. 1981–84 тә ВАСХНИЛның Зоотехника бүлеге акад.-секретаре. 1984–2002 дә К.А.Тимирязев исем. Мәскәү а.х. академиясенең сөт һәм ит терлекчелеге каф. мөдире. РФнең сөт терлекчелеге тармагында әйдәп баручы белгечләрнең берсе. Мөгезле эре терлекләрнең швиц токымы б-н нәсел эше планын, соры токымнарны сөт җитештерүнең интенсив технологиясенә җайлаштыруны камилләштерү ысулларын эшли. С. җитәкчелегендә швиц токымлы мөгезле эре терлекләрнең 5 завод линиясе булдырыла. Сөт терлекчелегендә эре масштаблы селекция теориясе авторларыннан берсе. 4 монография, а.х. юнәлешендәге югары уку йортлары өчен 8 дәреслек авторы (автордаш). Уйлап табуга 9 авторлык таныклыгы бар. «Зоотехния» ж-лының редколлегия әгъзасы.

Х е з м.: Формирование массива нового типа скота швицкой породы // Зоотехния. 1994. № 4; Селекция костромского скота на молочный тип // Зоотехния. 1995. № 1; Использование генетических маркеров в селекции швицкого скота // Зоотехния. 1995. № 4; Технология производства молока и говядины: Учеб. для с.-х. вузов. М., 1995 (автордаш).

*Ә.Х.Фазылҗанов, Г.С.Шәрәфетдинов.*

**СОЛДА́ТОВ** Виктор Павлович (22.9.1958, Әлмәт р-ны Түбән Мактама эшчеләр пос.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1985). Хезмәт эшчәнлеген 1979 елда Миңлебай нефть эшкәртү з-дында технол. җайланмаларны ремонтлау буенча слесарь булып башлый. 1981–82 дә батырма электр насослары з-дында эшли (Әлмәт ш.). 1985–94 тә Самара «Прогресс» з-дында цех участок мастеры. 1994–98 дә юл төзелеше пр-тиеләрендә (Әлмәт ш.). 1998 дән «Лениногорскнефть» НГДУында аппаратчы, автомобиль шиннары пиролиз җайланмалары башлыгы. Авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге экологик чиста технологияләрне эшләгәне һәм гамәлгә керткәне, тузган шиннарны ваклап утильләштерү өчен модульле җайланмалар комплексын сәнәгатьтә җитештерүне оештырганы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**СОЛДА́ТОВ** Георгий Иванович (23.2.1919, Мәскәү — 16.3.1992, Казан), архитектор. ТАССРның атказ. төзүчесе (1978). 1939 елдан, Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң, «Гипроавиапром» ин-тында эшли. 1941–45 тә Совет Армиясендә, Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946 дан ТАССР МСның Архит-ра эшләре идарәсендә, 1951 дән «Татпроект» конторасы проектлары баш архитекторы. 1957–71 дә Казан архитекторы, 1971 дән «Татгражданпроект» ин-тының генпланнар бүлеге башлыгы, 1977 дән «Казгражданпроект» ин-тында. 1988 дән Казанның дежур план секторы башлыгы. 1958–72 дә СССР Архитекторлар берлегенең Татарстан бүлеге идарәсе секретаре. П.А.*Саначин* б-н бергә проектлау эшчәнлеге алып бара (иң әһәмиятлеләре — 1950 нең 1 нче яртысына — сугыштан соңгы неоклассицизм һәм совет чоры ампирына туры килгән ген. планнар, детальле планлаштырулар, төзелеш проектлары). Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*С.П.Саначин.*

**СОЛДАТЧАЛА́Р**, к. *Кызыл канатсыз кандалалар*.

**СОЛИКА́МСК** шәһәре, *Пермь краеның* төньягында, Пермь шәһәреннән 368 *км* төньяктарак урнашкан. 1430 елда нигез салына. Халкы — 95828 кеше (2013). Татарлар саны: 1959 да — 1402, 1970 тә — 1456, 1979 да — 1459, 1989 да — 1545, 2002 дә — 1323, 2010 да — 1116 кеше. 1989 дан «Кардәшләр» татар-башкорт иҗтимагый үзәге эшли, аның каршында «Бәйрәм» ансамбле оештырыла. Сабан туе уздырыла.

**СОЛИТЁРЛАР** (Taeniidae), Cyclophyllidea отрядыннан тасма суалчаннар семьялыгы. Гәүдәсе 3 *мм* дан (3–7 буынтыклы) 10 *м* га (1 мең буынтыктан артык) кадәр. Башында имгечләре һәм ыргаклы (кайвакыт алар юк) хортумчыгы бар. Җитлеккән аналык күкәйләр б-н тула. 15 ыругы, 100 гә якын төре билгеле. Кеше, кош, ерткыч имезүчеләр һ.б. хайваннарның эчәклегендә паразитлык итәләр. Үсеш циклы катлаулы, бер арадаш хуҗалы (тояклылар, кимерүчеләр, сирәк кенә ерткычлар). Күкәйдән тышкы тирәлеккә эләккән личинкалар коры җирдә җитлегә. Арадаш хуҗаның тәненә эләгеп, ул төрле төрләрдәге финналарга (цистицерк, ценур, эхинококк һ.б.) әверелә, тән куышлыгында, эчке органнарда яки мускулатурада урнаша. Кеше өчен аеручы куркыныч булган дуңгыз С.ы (Taenia solium) личинкалары дуңгыз мускулларында паразитлык итә, үгез С.ы (Taeniarhynchus saginatus) личинкалары мөгезле эре терлек мускулларында туплана. Йоктыру чыганагы — җитәрлек дәрәҗәдә термик эшкәртелмәгән ит.

*О.Д.Любарская.*

**СОЛИФЛЮ́КЦИЯ** (лат. solum — туфрак, җир һәм fluxus — агыш), авырлык көче тәэсирендә авышлык буйлап грунтның юеш көпшәк, күбесенчә балчыксыл массаларының үзле-пластик агуы. Сезонлы туң катлам эрегәндә, 2–3 тән 10–15° ка кадәр текәлектәге тау битләрендә бара. Тизлеге буенча акрын (елына берничә *см*) һәм тиз (көчле) агымлы (елына берничә *дм*) С.не аерып йөртәләр. ТР терр-ясендә сөзәклекләрдә туң грунт эрегәндә, җир асты сулары өскә чыккан урыннарда, эрүче кар көртләре янында күзәтелә. Бозлык чорында мәңгелек туңлык шартларында С. барлык җирдә дә күзәтелгән, ә инде төньяк һәм көнчыгыш экспозицияләренең аз җылынучан һәм шул сәбәпле нык дымлы тау битләрендә көчлерәк барган. Шушы аермалыклар нәтиҗәсендә Татарстан терр-ясе өчен хас асимметрияле кече елга һәм сыза үзәннә-



В.В.Солнцева.

ре (к. *Сөзәклекләр асимметриясе*) формалаша. С. калын (3–5 тән 30–35 *м* га кадәр) делювиаль-солифлюкцион сөзәклек утырмалары (шлейфлар) — саргылт-көрән яки коңгырт-көрән карбонатлы комсыл балчыклар барлыкка китерүче яссы юылу б-н бара. ТРның хәзерге заман рельефында С. мәйданы 30–35% ка җитә. Бозлык алды һәм бозлыгара шартларның дүртенчел чор дәвамында берничә тапкыр алышынуы аркасында бер-берсе өстенә капланган һәм күмелгән туфрак горизонтлары б-н бүленгән 3–4 шлейф генерациясе формалашкан. Бу утырмаларда игенчелектә киң кулланылучы аеруча уңдырышлы туфраклар барлыкка килгән. Комсыл балчыклар чимал буларак кирпеч җитештерүдә кулланыла.

*Әд.:* Д е д к о в А.П. Экзогенное рельефообразование в Казанско-Ульяновском Поволжье. К., 1970; Б у т а к о в Г.П. Плейстоценовый перигляциал на востоке Русской равнины. К., 1986.

*В.И.Мозжерин.*

**СО́ЛНЦЕВ** Гавриил Ильич (22.3.1786, Орёл губ., Дмитровский өязе Радогощ а. — 29.11.1866, Казан), хокук белгече, хокук д-ры (1814), статский советник (1829). Руханилар катлавыннан. Орёл руханилар семинариясен тәмамлый (1807). 1807–11 елларда Орёл губернасы идарәсе чиновнигы. 1811–14 тә Сенатның 7 нче (Мәскәү) департаменты канцеляриясендә. 1814–23 тә Казан ун-тында: 1815–16 да экстраординар проф., 1816 дан иң күренекле борынгы һәм яңа халыклар хокукы каф. ординар профессоры, бер үк вакытта, 1818–19 да, әхлакый-сәяси фән. бүлеге деканы, проректор, 1819–20 дә ректор. Казан уку-укыту округы попечителе М.Я.Магницкий б-н табигый хокук фәнен укыту алымнары мәсьәләсендә каршылыкка кереп, 1821 дә ун-т мәхкәмәсе хөкеменә бирелә, аның карары буенча 1823 тә укыту өлкәсеннән китә. 1824–44 тә Казан губернасы прокуроры. 1844–45 тә Юстиция министрлыгы департаментына беркетелә. Казан губернасындагы төрле җинаятьләр һәм тәртип бозуларга каршы көрәшә. Табигый хокук мәктәбе тарафдары. «Россия җинаять эшләре хокукы» («Российское уголовное право», 1820; басыла: Ярославль, 1907) дәреслеге авторы. Кульъязмалары табигый хокук, Рим һәм гражданлык хокукын, дәүләт һәм хокук теориясен өйрәнүгә багышлана. Казанда *Родионованың затлы нәсел кыз балалар институты* ачылуга булышлык итә (1841). Казан рус әдәбиятын сөючеләр җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы (1813). Төрмәләр буенча Казан попечительләр ком-ты әгъза-директоры (1833–44).

*Әд.:* Б у л и ч Н.Н. Университетский суд над профессором Солнцевым во время попечительства Магницкого // Уч. зап. Казан. ун-та. 1864. Вып. 1; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; А г а ф о н о в Н.Я. Из Казанской истории. К., 1906; Ф е л ь д ш т е й н Г.С. Русский криминалист 20-х годов XIX века Гавриил Ильич Солнцев // Журн. М-ва юстиции. 1906. № 4–5; Е м е л ь я н о в а И.А. Гавриил Ильич Солнцев, 1786–1866. К., 2003; Б а г а у т д и н о в Ф.Н. Человек громадной учёности: о Г.И.Солнцеве. К., 2011.

*Е.Б.Долгов.*

**СО́ЛНЦЕВ** Роман Харис улы (чын фамилиясе һәм исеме Суфиев Ринат) (21.5.1939, Минзәлә р-ны Кузкәй а. — 17.4.2007, Красноярск ш.), язучы, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1989). Рус телендә яза. Казан ун-тын (1962), А.М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлый (Мәскәү, 1973). 1961 елдан Красноярск шәһәрендә яши, Политехник ин-тта укыта, өлкә газеталарында хәбәрче була, Себер геол. партияләрендә эшли; 1994 тән «День и ночь» ж-лы мөхәррире. 1989 дан Россия язучылары берлегенең («Союз российских писателей») Красноярск төбәк оешмасы рәисе, 1992 дән рус Пен-үзәгенең Себер ф-лын җитәкли. «Мәңгелек урманнар» («Вечные леса», М., 1969), «Бүген әйт» («Скажи сегодня», Красноярск, 1979), «Кайту» («Возвращение», М., 1984), «Могҗизалы еллар» («Волшебные годы», Красноярск, 1997), «Көмеш шнур» («Серебряный шнур», Красноярск, 2005) шигырь җыентыклары авторы. С.ның шигырьләрендә туган як турында сагынулы истәлекләр урын ала («Атам йорты» — «Отчий дом», «Балачак әкиятләре» — «Сказки детства», «Әни» — «Мама», «Татар вальсы» — «Татарский вальс», «Киң кыр» — «Чистое поле», «Минзәлә» — «Мензелинск», «Мин яңадан монда, ватанымда...» — «Я снова здесь, на родине моей...»). Геройның Ык буендагы туган йортына кайтуы турындагы «Ак ярлар» («Белые берега», 1985) повестенда, Камада автозавод төзүче яшьләргә багышланган «Яшел калкулыкларда кызыл ат» («Красная лошадь на зелёных холмах», М., 1976) повестенда, «Көймә ватылса — утын» («Лодка пойдёт на дрова», 1978), «Гафу ит мине, Бажанов» («Прости меня, Бажанов», Красноярск, 1988) повестьларында, «Тарзан кычкыруы» («Крик Тарзана», 2000), «Агалы-энеле умартачылар» («Братья-пасечники», 2007) хикәяләрендә дә әлеге тема урын ала. С. кискен сюжетлы күпсанлы социол.-психол. проза һәм драматургия әсәрләре авторы: «Синең исемең бердәнбер» («Имя твоё единственное», М., 1973), «Рябина күпере» («Мост на Рябине», Красноярск, 1988), «Аю аэропорты» («Аэропорт Медведь», М., 1989), «Алтын баскычтагы кешеләр һәм җанварлар» («Люди и звери на золотой лестнице», М., 1994), «Бер эздән ике тапкыр» («Дважды по одному следу», Красноярск, 1997), «Ярымтаркалыш» («Полураспад», Красноярск, 2003), «Платонова белән әңгәмәләр» («Диалоги с Платоновой», СПб, 2006). 1970–90 елларда С. пьесалары буенча Мәскәү, Ленинград, Красноярск, Казан һ.б. шәһәр театрларында «Ана һәм ул» («Мать и сын»), «Безнең әби — Гулливер» («Наша бабушка — Гулливер»), «Ышанам һәм барам» («Поверю и пойду»), «Кеше көтәбез» («Ждём человека»), һ.б. спектакльләр куела. Геройлары ярата, газаплана. Илдә барган үзгәрешләрне аңларга омтылган «Кара комедия» («Чёрная комедия», 1980), «Мәхәббәт турында куркыныч әкият» («Страшная сказка про любовь», 1990), «Үземнең, үземә таныш булмаган гомерем» («Моя, мне неизвестная жизнь», 1992) һ.б. пьесалар авторы. 1980 елларда С. сценарийлары буенча «Мине шундый итеп истә калдырыгыз» («Запомните меня такой», реж. П.Чухрай, 1987) исемле нәфис фильм, «Кызыл келәмдә өчәү» («Трое на красном ковре», реж. В.Бровкин, 1988) исемле телефильм, «Күкләрдә туктап калу» («Торможение в небесах», реж. В.Бутурлин, 1989; 1993 тә Страсбург шәһәрендә узган фестивальдә Гран-при лауреаты) нәфис фильмы һ.б. төшерелә. 1989–91 елларда СССР халык депутаты. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Ключи, подаренные друзьям. Красноярск, 1989; Восторженный беглец: Избр. стихи, повести, рассказы. Красноярск, 1994; Дюжина пьес весёлого времени. Красноярск, 1999; Избр. стихотворения: В 2 кн. Красноярск, 2004.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

*Г.А.Балакин.*

**СО́ЛНЦЕВА** Вера Васильевна (23.10.1933, Горький өлкәсенең Пилнә р-ны Левашёвка а. — 23.6.2014), станокта эшләүче, Соц. Хезмәт Герое (1976). 1951–92 елларда В.И.Ленин исем. Казан фәнни-җитештерү пр-тиесендә эшли, махсус эшләнмәләр җыючылар бригадиры (1969–79). Герой исеме җитештерүдә махсус техника булдыруга һәм үзләштерүгә керткән өлеше өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**СО́ЛНЫШКИНА** Марина Ивановна (26.3.1961, Октябрь р-ны Октябрь урман хуҗалыгы), тел белгече, филол. фән. д-ры (2005), проф. (2006). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1984). 1994–2000 елларда шунда ук укыта, 2006 дан теоретик һәм гамәли лингвистика каф. мөдире, 2009 дан Чит телләр ин-ты директоры урынбасары. Хезмәтләре тел белеме теориясенә, чагыштырма тел белеменә, социолингвистикага багышлана.

Х е з м.: Общие вопросы теории фразеологии. Саратов, 1995; Введение в сравнительное языкознание: Учеб. пособие. К., 2004.

*Әд.:* Учёные Татарского государственного гуманитарно-педагогического университета. К., 2008.

**СОЛОВЦО́ВО** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 20 *км* төньяктарак, Сола елгасы (Казансуның уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 33 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 1597 дән Черас исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Богородский, Митрий, Черас буларак та мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр хал-

ĸы алпавыт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлек асрау, мичкә, арба ясау, йон тукыма ману, он тарту, балта эше, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Смоленск Богородица чиркәве (1735 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1881 дә ачыла), кредит ширкәте, 4 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 859 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Алат волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1646 да – 92, 1782 дә – 222 ир-ат; 1859 да – 452, 1897 дә – 593, 1908 дә – 691, 1920 дә – 661, 1926 да – 685, 1938 дә – 623, 1949 да – 460, 1958 дә – 344, 1970 тә – 233, 1989 да – 69, 2002 дә – 65 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**СОЛОВЬЁВ** Александр Титович (6.11.1853 – 3.12.1918, Казан), нашир, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, Казан губернасында аеклар һәм уң монархиячел хәрәкәтләр җитәкчеләренең берсе, коллегия асессоры. 1870 елда Тәтеш өяз уч-щесен тәмамлый. Балахнино приход уч-щесендә, Биләр, Казанның 2 нче һәм 7 нче башлангыч уч-щеләрендә укыта; 1884 тән университет басмаханәсе башлыгы. 1885 тән беренчеләрдән булып Россиядә халык аеклыгы өчен көрәш башлый. Эчкечелекнең зыяны турында бәян ителгән, берничә тапкыр басылган «Шәраб – кеше һәм аның нәселе өчен агу» («Вино для человека и его потомства – яд», М., 1888; 21 нче басма, 1914) брошюрасы авторы. Л.Н.Толстой б-н хат алыша. Толстой С.ка эчкечелеккә каршы китаплар чыгарырга ярдәм итә, ул «Без, А.Т. [Соловьёв] б-н Россиядә беренчеләрдән булып эчкечелеккә каршы көрәш башладык», – ди. *Казан аеклар җәмгыятен* оештыручыларның берсе һәм рәисе, аның җитәкчесе буларак, Туриндагы Бөтендөнья сәнәгать күргәзмәсендә Зур көмеш медальгә лаек була (1911). «Казан шәһәрендә авыр хәлдә калган хатын-кызларны яклау җәмгыяте»нең 1 нче рәисе (1900). 1886–90 да «*Справочный листок*» г-тасы, 1896–1917 дә «*Деятель*» ж-лы мөхәррире, 1905–15 тә «*Русь православная и самодержавная*» г-тасы мөхәррире һәм нашире. Казан ун-ты басмаханәсендә нәшер ителгән китаплар каталогын төзи. Аның 2 нче басмасы Н.Ф.*Катанов* әзерләгән Шәрекъ бүлеге китаплары каталогы, авторлар, тәрҗемәчеләр һәм наширләрнең алфавит тәртибендә төзелгән исемлеге б-н тулыландырыла. Рев-циягә һәм либераль реформаларга каршы була, «*Рус халкы берлеге*» лидеры А.И.Дубровин тарафдары. 1905–17 дә «Рус җыены»ның Казан бүлеге рәисе. Бөтенроссия монархистлар съездларында һәм киңәшмәләрендә катнаша. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында яралы сугышчыларга һәм качакларга ярдәм оештыручыларның берсе. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң сәяси һәм иҗтимагый эшләрдән ераклаша, кулга алына. 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары, Александров тасмасында көмеш медаль, Кызыл Хач билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Друг школы: Первая книга после азбуки. М., 1890; О табаке: Средство избавиться от многих болезней. К., 1910; К вопросу о борьбе с пьянством, преступностью и нищенством. О домах трудолюбия. К., 1914.

*Әд.:* А л е к с е е в И.Е. На страже Империи. К., 2006. Вып. 1; Воинство Святого Георгия (жизнеописания русских монархистов начала XX века). СПб., 2006.

*И.Е.Алексеев.*

**СОЛОВЬЁВ** Валерий Дмитриевич (1.6.1952, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (1996), проф. (1997). 1974 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, теоретик кибернетика каф. профессоры (1998 дән), бер үк вакытта, 2001 дән, Информатика ин-тының директор урынбасары һәм когнитив фән. лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре матем. логикага һәм когнитив фәннәргә карый. А.П.Ершов һәм А.А.Ляпуновның машина командалары системасы тулылыгы мәсьәләсен чишә, шәһәрләрдә һава чисталыгын эксперт тикшерү системасын гамәлгә кертә, рекурсив функцияләрнең программалы алгебралары теориясен төзи. Казан ун-тының электрон сирәк китаплар китапханәсен төзүне оештыра.

Халыкара «Web Journal of Formal, Computational and Cognitive Linguistics» электрон ж-лының баш мөхәррире (1997 дән). Татарстанда го уенын популярлаштыручы. Го уены буенча команда беренчелегендә Россия гроссмейстеры (2004), РСФСР чемпионы (1987), Европа чемпионы (1988, 1990, 1992), шәхси беренчелектә Европа чемпионатының бронза медале иясе (1988/89). Россиянең го уены федерациясе президенты (1994–97), мактаулы президенты (1998дән).

Х е з м.: Алгебраические аспекты абстрактной теории вычислимости // Мат. вопр. кибернетики. 1991. Вып. 3; Абстрактная теория вычислимости: программистский подход. К., 1993; Программные алгебры рекурсивных функций // Успехи мат. наук. 1996. Т. 51, № 4.


**СОЛОВЬЁВ** Виктор Николаевич (13.2.1949, Бондюг эшчеләр пос.), музей эшлеклесе. Казан химия технол. ин-тын тәмамлый (1979). 1966–69 һәм 1971–91 елларда Л.Я.Карпов исем. химия з-дында (Менделеев ш.), профсоюз ком-ты рәисе (1983–85), «Заводская трибуна» г-тасында мөхәррир (1989 дан) булып эшли. С. тырышлыгы б-н 1978 елда завод музее, 1991 дә *Менделеев төбәк тарихы музее* (1991–2011 дә директоры) оештырыла. С. эшләгән вакытта регионның күчемле һәм күчемсез мәдәни мирас объектларын саклау буенча шактый эш башкарыла. Музей Татарстанда беренчеләрдән булып музейларның автоматлаштырылган компьютер мәгълүмат системасына күчә (КАМИС). 1999 да ТР МК карары нигезендә музей бинасын һәм бина тирәсендәге 5,1 *га* гомуми терр-яне берләштергән «Ушковлар утары» тарихи-мәдәни һәм табигый терр-я оештырыла. Музей ТРның мәдәни мирасын саклау буенча комплексы максатчан «Мирас» – «Наследие» программасына кертелә. 2002 дән «Менделеевский музейный вестник» ж-лы чыга, төбәкне өйрәнү буенча Ушков укулары үткәрелә.

Х е з м.: Через музей в XXI век. Менделеевск, 1999; Нужна культура мира, или Каким быть музею XXI века // Аргамак. 1999. № 4.

**СОЛОВЬЁВ** Никифор Сергеевич (1894, Казан губ., Мамадыш өязе Зур Мәшләк а. – 1967, Казан), сәясәт эшлеклесе. Изге Гурий бордәрлеге мәктәбен тәмамлаганнан соң, Үзәк керәшен татар мәктәбендә укый. Казан укытучылар семинариясен тәмамлый (1913). Мамадыш өязенең Янил авылында ике сыйныфлы земство уч-щесе мөдире. Беренче бөтендөнья сугышында, 1917 елгы Февр. һәм Окт. рев-цияләрендә катнаша; сул эсер, 1918 дән РКП(б) әгъзасы. 1918–19 да Көнчыгыш фронтның 1 нче армиясендә революцион трибунал рәисе. 1920–21 дә РСФСРның Милләтләр эшләре буенча халык комис-тында Үзәк керәшен бүлеге хезмәткәре. 1922–28 дә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тында Керәшеннәр секциясе бюросы әгъзасы, 1923–28 дә ТАССР ҮБК әгъзасы, 1927–30 да ТАССР мәгариф халык комиссары урынбасары. Югары пед. ин-тының (Мәскәү) берьеллык курсларын тәмамлаганнан соң, СССР Кулланучылар кооперациясе академиясенең социаль-икътисади фәннәр каф. мөдире (1931–33). 1935 тән Казанда: Казан а.х. ин-ты директоры, Казан авиация һәм Казан вет. ин-тларында кафедралар мөдире, 1941–45 тә хәрби уч-щеләрдә укыта, сугыштан соңгы елларда Татарстан респ-ка партия мәктәбенең һәм Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тының ВКП(б) тарихы һәм марксизм-ленинизм кафедралары мөдире, аннан соң Казан ун-тының КПСС тарихы каф. укытучысы.

*Әд.:* Г л у х о в М.С. Соловьёв Никифор Сергеевич // Борцы за счастье народное. К., 1988. Кн. 3.

**СОЛОВЬЁВ** Сергей Михайлович (5.5.1820, Мәскәү – 4.10.1879, шунда ук), тарихчы, тарих фән., сәяси экономия һәм стат. д-ры (1847), Петербург ФА академигы (1872; 1864 елдан мөхбир әгъза), яшерен советник (1871). Руханилар катлавыннан. Революциягә кадәрге рус тарих фәненең күренекле вәкиле; Ватан историографиясендә дәүләт мәктәбен оештыручыларның берсе. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1842); 1845–77 елларда шунда ук эшли: адъюнкт (1847 гә кадәр), 1847–50 дә экстраординар проф., 1850–70 тә ординар проф., 1870 тән рус тарихы каф. атказ. профессоры; 1864–70 тә Тарих-филол. ф-ты деканы, 1871 дән ректор. 1877 дән Мәскәү Тарих һәм Россиянең борынгы ядкәрләре җәмгыяте рәисе, бер үк вакытта, 1877 дән, Кораллар палатасы директоры. Карашлары б-н көнбатышчылар төркеменә карый, урталыктагы либераль позициядә тора. «Борынгы дәверләрдән бирле Россия тарихы» («История России с древнейших времён», 1–29 т., М.-СПб., 1851–79) фундаменталь хезмәтендә Россиянең 9–19 йөзләр дәвамындагы тарихының бөтенлекле манзарасын тудыра. Н.М.Карамзин җитәкчелегендә дворяннар



С.М.Соловьёв.

историографиясе булдырган концепцияне тәнкыйтьли. Россия тарихын яктыртканда «норманнар» һәм «татарлар» чорларын аерып күрсәтүдән баш тарта, ыру-кабилә мөнәсәбәтләренең дәүләт мөнәсәбәтләренә күчүенә төп рольне биреп, үзәккә яулап алуларны түгел, ә эчке үсеш процессларын куя. С., тарихи-чагыштыру алымы тарафдары буларак, Россия һәм Көнбатыш Европа үсешенең уртак сыйфатларын күрсәтеп, Россиянең урталыкта булып, күчмә дала халыклары, ш.у. Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Идел буе, Кырым һәм Себер татар ханлыклары б-н гасырлар буе дәвам иткән мәҗбүри көрәшеннән гыйбарәт үзенчәлеген билгели. С. үзенең хезмәтләрендә рус тарихын чорларга бүлү, халыкларның тарихи язмышына тәэсире, Россия дәүләтенең этник төзелеше, русларның колонияләштерү сәясәте һәм аның юнәлеше мәсьәләләрен күтәрә. Тарихи үсешне дәүләт формасын үзгәртүгә кайтарып калдырып, сәяси тарих б-н чагыштырганда иҗтимагый-икътисади тормыш тарихын буйсынган хәлгә куя. С. концепциясендә рус халкының күчмә халыклар б-н көрәше Европа б-н Азиянең ярышу формасы, Европа «холкының» — Азия «холкы», утрак халыкның — дала урдалары, мәдәният һәм гражданлыкның күчмә тормыш б-н бәрелеше буларак алга сөрелә. С. фикеренчә, башта Азия «һөҗүм итә», 16 йөздән Россия көнчыгышта Европаның алгы форпосты ролен үти. С. монголлар һөҗүменең Русьның алдагы иҗтимагый үсешенә, рус дәүләтчелеге формалашуга тәэсир итүче факторларына зур әһәмият бирми. Ул монголлар яуланган терр-ядән бик тиз китеп барганнар, «еракта яшәргә калып, ясак җыю турында гына кайгыртканнар, барысын да ничек булган шул хәлдә, ягъни аларга кадәр башланган мөнәсәбәтләрне кагылгысыз калдырып, эчке мөнәсәбәтләргә бөтенләй тыкшынмаганнар», дип исәпли. Ханнар, кенәзлек итүгә ярлыклар өләшеп һәм рус чиркәүләрен яклап, кенәзләр арасындагы үзара сугышларда «корал» гына булганнар, дигән фикердә тора. С. Мәскәү кенәзләренең милли азатлык көрәше барышында Мәскәүне барлык рус кенәзлекләре үзәгенә әверелдергән, монголлар изүенә каршы юнәлтелгән шәрекъ сәясәтен күзәтә. С. тарафыннан 1380 дәге *Куликово кыры сугышы* дөньяви тарихи әһәмияткә ия аеруча мөһим вакыйга буларак бәяләнә, аның фикеренчә, 15 йөз ахырында изүне бетерү үзәкләштерелгән Рус дәүләте барлыкка килү б-н бәйле. «Россия тарихы»нда мөһим урыннарның берсе Явыз Иванның патшалык итүен — дәүләт мөнәсәбәтләре тәмам җиңгән һәм самодержавие урнашкан заман турында хикәяләүгә бирелә. С. өчен Казан, Әстерхан һәм Себерне яулау — Россиянең Шәрекъкә һөҗүмгә күчеше күрсәткече, Азияне әкренләп буйсындыруның башлангычы. «Польшаның җимерелү тарихы» («История падения Польши», М., 1863), «Яңа тарих курсы» («Курс новой истории», ч. 1–2, М., 1869–73), «Император Александр I. Сәясәт, дипломатия» («Император Александр I. Политика, дипломатия», СПб., 1877) монографияләре «Россия тарихы»ның үзенчәлекле дәвамы булып торалар. Аларда 18 йөзнең ахырында — 19 йөзнең 1 нче яртысында Россиянең тышкы һәм эчке сәясәте мәсьәләләре яктыртыла. Галимнең Пётр I б-н кызыксынуы аның турында махсус лекцияләр циклы язуга китерә. С. хезмәтләре рус тарих фәненең үсешендә яңа дәвер ачып җибәрәләр һәм аннан соңгы Ватан тарихчыларына да йогынты ясыйлар.

Х е з м.: Учебная книга по русской истории. М., 1859; Публичные лекции о Петре Великом. М., 1872; Избранные труды. Записки. М., 1983; Сочинения: В 23 кн. М., 1993–2000.

*Әд.:* Б е з о б р а з о в П.В. С.М.Соловьёв: его жизнь и научно-литературная деятельность: Биогр. очерк. СПб., 1894; И л л е р и ц к и й В.Е. Сергей Михайлович Соловьёв. М., 1980; Ч е р е п н и н Л.В. Отечественные историки XVIII–XX вв. М., 1984; Ц и м б а е в Н.И. Сергей Соловьёв. М., 1990. *Е.Б.Долгов.*

**СОЛОВЬЁВ** Тимерша Салаватулла улы (1875, Казан губ., Зөя өязе Шуширмә а. — 1947, Мәскәү), нашир, журналист. «Касыймия» һәм «Мәрҗания» мәдрәсәсендә, Казан татар укытучылар мәктәбендә укый. 1902 елдан Казан икееллык рус-татар мәктәбендә укыта. Шул ук вакытта беренче әдәби әсәрләрен бастыра, эшчеләрнең сәяси түгәрәкләренә йөри башлый, шул сәбәпле губернатор карары б-н укытучылык эшчәнлегеннән читләштерелә (1903). Оренбург шәһәренә, аннан Түбән Новгородка күчеп китә, Г.Тукай катнашында татар музыка концерты һәм театр постановкалары уздырыла торган «Двухсветная» кунакханәсендә идарәче булып эшли. 1906 ның 20 июненнән 1910 ның маена кадәр үзе дә актив рәвештә басылган «*Чүкеч*» сатирик ж-лының нашире һәм мөхәррире була. 1907 дә «*Урал*» г-тасы нашире. 1908 дә газета редакциясе мәхкәмә җаваплылыгына тартыла һәм 1917 гә кадәр полиция күзәтүендә була. 1920 дә Казанда яши, адм.-хуҗалык эшләре б-н шөгыльләнә. 1933 тә Алма-Ата шәһәренә күченә, банк хезмәткәре, мәктәп директоры булып эшли. 1935 тән Мәскәүдә яши.

Х е з м.: Мужик илә мулла, яки Карт хәзрәт корган тозак. Оренбург, 1902; Биби-Казан. Оренбург, 1905; Ишан Хәдичәсе. Оренбург, 1906; Мәктәп вә мәдрәсәләрне Духовный собраниегә бирү. Оренбург, 1908.

*Әд.:* Г ы й м а д и е в Ү. Сатира коралы белән. К., 1977; Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Библиогр. сүзлек. К., 2005. *М.И.Әхмәтҗанов.*

**СОЛОВЬЁВА** Светлана Евгеньевна (9.4.1955, Казан), химик-органик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008), химия фән. канд. (1980). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1977), шунда ук эшли. 1995 тән РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында. Хезмәтләре органик (гетероциклик һәм макроциклик) кушылмалар синтезына һәм аларның структурасын өйрәнүгә, каликсареннар химиясенә карый. С. төрле фәзаи структуралы (конус, өлешчә конус һәм 1,3-альтернат), металл ионнарының перспектив комплекс ясагычлары булып торучы күп кенә тетраалмаш каликс[4]ареннар һәм тиакаликс[4]ареннар синтезлый. Дәүләт бүләге «Каликсареннар нигезендә супрамолекуляр системалар» хезмәте өчен бирелә. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы һәм патентлы бар.

Х е з м.: Дизайн и ионофорные свойства ряда макроциклических лигандов на основе каликсаренов // Координационная химия. 2004. Т. 30, № 4 (автордаш); Синтез, строение и комплексообразующие свойства тетраамидов тиакаликс[4]арена в различных конформациях // Изв. РАН. Сер. хим. 2005. № 9 (автордаш); Синтез и комплексообразующие свойства карбонилсодержащих тиакаликс[4]аренов // Изв. РАН. Сер. хим. 2008. № 7 (автордаш).

**СОЛОВЬЁВКА** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 31 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Мари Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 2 кеше (руслар) яши. 1919 да нигез салына. Оешкан көненнән Казан губернасының Казан өязе Кукмара волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1920 дә — 159, 1926 да — 139, 1970 тә — 110, 1979 да — 23, 1989 да — 12, 2002 дә — 3 кеше.

**СО́ЛОДЛАР**, туфраклар тибы, юыла һәм даими юыла торган су режимы шартларында урман-дала һәм дала зоналарында агач-куак яки болын үсемлекләре астында формалаша. Катыр туфракларның тозлануы барышында, еш кына микротүбәнлекләрдә (усак, каен агачлыкларында), ш.у. җиңелчә минеральләшкән натрийлы эремәләрнең туфракка даими йогынтысы нәтиҗәсендә барлыкка киләләр. Солодлану процессына хас үзенчәлекләр: селтеле реакция һәм суның сеңмәве аркасында туфракның өске катламындагы минералларның таркалуы, ләмле һәм коллоидлы кисәкчекләрнең профильнең өске өлешеннән уртага күчүе, өске өлештә аморфлы кремний диоксиды туплану. Шуның б-н бергә аксыл яки ачык соры төстәге элювиаль $A_2$ горизонты (С. профиле *көлсу туфраклар* төзелешен хәтерләтә) 5–20 *см* калынлыкта үсеш ала. ТР терр-ясендә С. кара туфраклар арасында зур булмаган мәйданнарда очрый; аларның гомуми мәйданы 1,4 мең *га*. Гумуслылыгы 2–8%, җиңелчә әче реакцияле, еш кына глейланган хәлдә. Көтүлек һәм печәнлек җирләр буларак файдаланыла. Мелиорация эшләре (органик һәм минераль ашламалар кертеп тирән сукалау) үткәреп, зур мәйданнарны а.х. культуралары үстерү өчен эшкәртергә мөмкин. *Ф.Г.Борһанов.*

**СОЛОДУ́ХО** Моисей Герцевич (23.1.1911, Царицын ш. — 3.6.1993, Казан), геолог-палеонтолог. Казан ун-тын тәмамлый (1934), шунда ук эшли (1938–92). Хезмәтләре палеонтологиягә, стратиграфиягә һ.б. карый. С. беренчеләрдән булып Россия терр-ясендә (Югары Ослан р-ны Печище а. янында) борынгы балыкларның берничә бөтен скелетын таба һәм аларны җентекләп тасвирлый,

Пермь системасы периоды фаунасының яңа төрен ачыклый. Идел буе Пермь утырмаларында риф ясаучы корылмалар булуын исбатлый, Казан ярусының горизонтларга биостратиграфик бүленешен эшли. Татарстан терр-ясендә минераль чишмәләр һәм шифалы ләмнәрне ача һәм тасвирлый, бу исә су һәм ләм б-н дәвалану йортлары ачылуга сәбәп була. Казан ун-ты геол. ф-тының тарихи-фәнни юнәлешен кабат торгыза. Күп кенә казылма хайваннар һәм үсемлекләр С. исеме б-н атала. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Путеводитель геологических экскурсий к Международному геологическому конгрессу «Пермская система земного шара». Свердловск, 1991 (автордаш).

*Әд.:* С о л о д у х о Н.М., С и л а н т ь е в В.В. Моисей Герцевич Солодухо, 1911–1993. К., 2003.

**СОЛОДУ́ХО** Натан Моисеевич (18.3.1952, Казан), философ, филос. фән. д-ры (1993), проф. (1995), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2007). Казан ун-тының физика ф-тын тәмамлаганнан соң (1974), Казан хисаплау техникасының фәнни-тикшеренү технол. ин-тында инженер булып эшли. 1979 елдан Казан пед. ин-тының филос. кафедрасында. 1996 дан Казан технол. ун-тының филос. каф. мөдире. Хезмәтләре филос. һәм фәнни белемнәрнең методологиясенә, онтологиягә, табигыять белемнәренең филос. мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Однородность и неоднородность в развитии систем. К., 1989; Гомогенно-гетерогенный подход в структуре гомогетерогеники. К., 2006; Ситуционный подход в контексте экологической философии. К., 2011 (автродаш).

**СОЛОДУ́ХО** Эдуард Моисеевич (22.7.1945, Тбилиси — 17.5.1997, Мәскәү, Казанда җирләнә), тел галиме, филол. фән. д-ры (1985), проф. (1986). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1966), шунда ук эшли. 1981 елдан Казан мед. ун-тында чит телләр каф. мөдире. Хезмәтләре гомуми тел белеме, лексикология, славян, герман һәм роман телләре фразеологиясенә, югары мәктәптә чит телләр укыту методикасына карый.

Х е з м.: Проблемы интернационализации фразеологии. К., 1982; Теория фразеологического сближения: На материале языков славянской, германской и романской групп. М., 2008.

**СОЛОМО́НОВ** Борис Николаевич (30.6.1947, Казан), химик, химия фән. д-ры (1987), проф. (1991). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1970), шунда ук эшли, органик кушылмаларның структурасын өйрәнү буенча проблемалы лаб. мөдире (1987–97), физик химия каф. мөдире (1997 дән), проректор (1992–2002). Хезмәтләре эремәләр һәм нәэлектролитлар термодинамикасына карый. С. нәэлектролитларның сусыз эремәләре термодинамикасы анализына яңача караш, ш.у. эксперименталь үлчәнгән термодинамик сольватлашу функцияләрен төзүчеләргә бүлә торган тигезләмәләр тәкъдим итә; эремәләрдәге молекулаара тәэсир итешүләр турында яңа күзаллаулар бәян итә. Эремәләрдә күмәк водородлы бәйләүне билгеләү алымнарын эшли, молекулалар һәм тирәлек структурасының бәйләү параметрларына тәэсирен тикшерә. Нәэлектролитлар гидратациясенең термодинамик функцияләрен анализлау алымы нигезендә гидрофоб эффектларның универсаль шкаласын төзи. Беренче булып эрегән матдәне су б-н водородлы бәйләүче термодинамик функцияләрнең микъдари күрсәткечләрен таба. Абразив материал өчен нигез кәгазь чыгаруның С. (бергәләп) эшләгән технологиясе Херсон целлюлоза-кәгазь комб-тында гамәлгә кертелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Термохимия сольватации органических неэлектролитов // Успехи химии. 1991. Т. 60, вып. 1 (автордаш); Quantitative description of the hydrophobic effect: The enthalpic contribution // Journal of Physical Chemistry. 2006. V.110 (18) (автордаш); Solution calorimetry of organic nonelectrolytes as a tool for investigation of intermolecular interactions // Journal of Physical Organic Chemistry. 2008. V.21(1) (автордаш); The hydrophobic effect Gibbs energy // Journal of Molecular Liquids. 2008. V.139 (1–3) (автордаш).

**СОЛОНИ́ЦА**, С о л о н к а елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Казансу елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 25,8 *км*, бассейнының мәйданы 147,6 *км*². Елганың шактый өлеше Биектау р-нында, зур булмаган участогы Яшел Үзән р-ны терр-ясендә. Елга башы Биектау р-ны Кече Кавал авылыннан төньяктарак, тамагы Казан чигендә, Кадыш авылыннан көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. С.ның 1,2 дән 9 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар, иң зурысы — Монастырь инеше (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км*². Туенуы катнаш, яртысыннан артыгы кар сулары өлешенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 202 *мм*, ташу агымы катламы 107 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Җир асты сулары чыккан урыннарда (Кадыш һ.б. авыллар тирәсендә) елга кыш дәвамында боз б-н капланмый. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,5 *м*³*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). С. һәм аның кушылдыклары ярларында җир асты сулары чыгышлары (Кадыш чишмәләренең дебиты аеруча югары, алар кушылганнан соң, С.ның чыгымы якынча 2 тапкыр арта) бар, ш.и. *Седмиозёрный пустыне* терр-ясендәге төзекләндерелгән 2 «изге» чыганак — православие динендәгеләрнең хач кылу урыны. С. бассейнында ландшафтлы табигать истәлеге *Семиозёрка урманы* (1986) һәм *Зәңгәр күлләр* табигать тыюлыгының бер өлеше (1994) урнашкан.

*О.Н.Урбанова, О.В.Ерёгин.*

**СОЛО́НКА** елгасы, к. *Солоница*.

**СОЛТА́Н** (гарәп. سلطان), мөселман илләрендә дәүләт б-н идарә итүче титулы; иң элек, гомумән, хакимиятне белдерү өчен кулланылган. 9–10 йөзләрдә, дини хакимияткә ия имамнардан аеру йөзеннән югары җәмгыять идарәчесен шулай атап йөрткәннәр. 11 йөздән — сәлҗүкләр, 13 йөзнең 2 нче яртысыннан — Мисыр мәмлүкләре идарәчеләре, 14 йөздән Госманлылар империясе идарәчеләре титулы. Алтын Урдада һәм ул таркалганнан соң барлыкка килгән татар ханлыкларында С. титулы хаким идарәчене аңлаткан. Хан мөһерләрендәге рәсми дәрәҗәләрдә «С.» термины эпитет сыйфатында идарәче исеме алдына, хан титулы әлеге исемнән соң куелган: әс-солтан Хаҗигәрәй хан (хаким Хаҗигәрәй хан), әс-солтан әл-әгъзәм Сәхибгәрәй хан (бөек хаким Сәхибгәрәй хан). С. титулы «хаким углы» (шаһзадә), «хаким кызы» мәгънәсен дә аңлаткан, бу очракта әлеге титул ялгызлык исемнән соң килгән: Габделлатыйф солтан, Маһи солтан һ.б. С. титулын Җүчи нәселенең аеруча озын гомерле ботагына караган казакъ ханнарының гаилә әгъзалары да йөрткән.

*Әд.:* Б а р т о л ь д В.В. Халиф и султан // Сочинения. М., 1966. Т. 6; У с м а н о в М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. К., 1979.

*М.Г.Госманов.*

**СОЛТА́Н** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Әшнәк елгасының (Кама елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 8,6 *км*, бассейнының мәйданы 39,8 *км*². Балык Бистәсе р-ны терр-ясендә ага. Елга башы Олы Солтан авылыннан 3,3 *км* төньяктарак, тамагы Зюзино һәм Наумово авыллары янында. Елга башының абс. биеклеге 110 *м*, тамагыныкы — 76 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. С.ның 0,4 тән 2,2 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,48 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 129 *мм*, ташу агымы катламы 120 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,013 *м*³*/с*. Язын суы каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гидрологик режимы язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**СОЛТА́Н МӘЧЕТЕ́**, Казандагы архит-ра истәлеге. 1867 елда Казан сәүдәгәре Ж.Б.Усманов акчасына төзелә. «Җиһанша мәчете», «Солтан мәчете», «Сигезенче җамигъ мәчет» исемнәре б-н йөри.

Мәчет квартал диагонале буенча урамнар кисешкән җирдә урнашкан. Проекты буенча бер катлы, җир өстендәге манарасы б-н бер заллы мәчет. Ишеге манара нигезендә уелган, манара дүрт кыеклы түбә б-н ябылган мәчет бинасына зур булмаган күләм б-н тоташкан. Аркылы дивары мәчетне вестибюльгә һәм биш кырлы михраб чыгынтысы көньяк фасадта урнашкан намаз залына бүлеп тора. Биек а́ркалы тугыз пар тәрәзә өстән зур булмаган икенче рәт парлы тәрәзәләр б-н тулыландырылган. Алар зал балконын яктыртып торалар һәм фасадларда парлы архивольт-

лар б-н төгәлләнәләр. Почмаклардагы киң терәткечләр һәм фигуралы кәрнизләр бинаның тышкы бизәлешен тәшкил итә. Өч яруслы манара конуссыман нәфис чатыр б-н очланган. Манараның күпкырлы тышлык б-н ябылган сигез кырлы нигезенә өченче катка илтүче эчке бормалы баскыч беркетелгән, мөәзәнә б-н уратып алынган цилиндрик кәүсә урнаштырылган. Манараның гамәлдә тәрәзәсез, кырыс кыяфәтендә шәһри Болгардагы манаралар б-н охшашлык бар.

1931 дә мәчет ябыла. Совет чорында залның бердәм күләме катларга бүленә; аслы-өсле, парлы, а́ркалы тәрәзәләр турыпочмак рәвешендә киңәйтелә, фасадларга өстәмә уемнар урнаштырыла, манара сүтелә.

Мәчет 1990 да арх. Н.Х.Халитов проекты буенча торгызыла. 1994 елда диндарларга кайтарып бирелә, 1990 еллар азагында реконструкция ясала, фасадларның әүвәлге кыяфәте яңартыла. Катлардагы эчке бүленеш сакланып кала.

*Әд.:* Халитов Н.Х. Архитектура мечетей Казани. К., 1991; Мечети Татарстана / Сост. Х.Г.Надырова, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хайрутдинов. К., 2000.

*Х.Г.Надыйрова.*

**СОЛТА́Н РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1944 елның 19 февралендә оештырыла. Үзәге — Олы Солтан авылы. 1920 гә кадәр район терр-ясе Казан губернасының Лаеш өязендә, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында, 1927 дән Лаеш һәм Балык Бистәсе р-ннарында. 1946 ның 5 апрелендә район үзәге Корноухово авылына күчкәч, район *Корноухово районы* дип үзгәртелә.

**СОЛТА́Н СӘЕ́Т КЫЗЫ́**, к. *Фатима Солтан.*


**СОЛТАНБӘ́КОВ** Булат Фәйзерахман улы (18.11.1928, Казан), тарихчы, тарих фән. канд. (1966), проф. (1996), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1950). 1947–50 елларда Шәмәрдән урта мәктәбендә укыта, 1950 дә КПССның Чүриле район ком-тында бүлек мөдире. 1953 тән Казанда: урта мәктәптә укыта, 1954–61 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында фән һәм мәктәпләр бүлеге инструкторы. 1961–71 дә Казан пед. ин-тында. 1971 дән — Казан мәдәният ин-тында, 1983 тән Казан консерваториясендә марксизм-ленинизм кафедралары мөдире, 1989 дан Казан ун-тының историография һәм чыганаклар белеме каф. доценты. 1992–2005 тә ТР Мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү ин-тының мәдәният каф. мөдире. Хезмәтләре СССРда милли-дәүләт төзелеше, Татарстанда сәяси репрессияләр тарихына, Татарстан һәм Россиянең күренекле дәүләт, фән һәм мәдәният эшлеклеләре тормышына карый. «30 нчы еллардагы сәяси репрессияләр: Законнар, башкаручылар, аклану» («Политические репрессии 30-х годов: Законы, исполнители, реабилитация», 1999) документлар җыентыгын төзүчеләрнең берсе, Татарстан һәм Казан тарихыннан уку ярдәмлекләре авторы. Тарихчы-архивистлар җәмгыяте идарәсе рәисе (1993–2003), Россия тарихчы-архивистлар җәмгыятенең Үзәк советы әгъзасы. Сәяси репрессияләр чоры корбаннарын аклауга зур өлеш кертә.

*Хезм.:* Драматические страницы истории Татарстана. К., 1993; История Татарстана: Страницы секретных архивов. К., 1994; Сталин и «татарский след». К., 1994; Татарстан XX век: Личности, события, документы: В 2 кн. К., 2003; Архивы и судьбы: Статьи, очерки, рецензии. К., 2006.

*Әд.:* Чернобаев А.А. Кто есть кто в изучении отечественной истории: Биобиблиогр. словарь. М.,1998.

**СОЛТАНБӘ́КОВ** Фәйзерахман Фәйзелхак улы (1892, Уфа губ., Минзәлә өязе Кәрәкәс а. — 1940), сәясәт һәм хуҗалык эшлеклесе. 1909 елда «Хөсәения» мәдрәсәсенә укырга керә, шәкертләр хәрәкәтендә катнашканы өчен аннан куыла. 1912–16 да Казан губернасының Мамадыш өязе, Вятка губернасының Алабуга өязе, Баку һәм Чимкент шәһәрләре мәктәпләрендә укытучы. 1916–17 дә Россия армиясендә хезмәт итә, 1917 дә 1 нче Себер запас полкының мөселман ком-ты рәисе. 1918 нең башында Кызыл Гвардия отрядына керә, Оренбург шәһәрендә атаман А.И.Дутов фетнәсен бастыруда катнаша. 1918 дә Башкортстанның Вакытлы Революцион Советы әгъзасы. 1919 да Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының икенче Бөтенроссия съездында катнаша. 1919–20 дә «Кызыл Шәрекъ» агитация поездының сәяси бүлеге каршындагы бюро мөдире. 1920–23 тә Бохара һәм Ташкентта кооперация җәмгыятьләре берлеге рәисе, аннан соң РКП(б) ҮК карамагына җибәрелә. 1924–30 да ТАССРда Авыл хуҗалыгы эшчеләре һәм батраклар профсоюзлары өлкә ком-ты рәисе. 1930–38 дә Казан коммуналь хуҗалык тресты җитәкчесе. Репрессияләр чоры корбаны.

**СОЛТАНГАЛИ́ЕВ** Мирсәет Хәйдәргали улы (25.7.1892, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Ялембәт а. — 28.1.1940, Мәскәү), сәясәт һәм дәүләт эшлеклесе, милли-дәүләт төзелеше теоретигы. Авыл укытучысы гаиләсеннән. Казанда Татар укытучылар мәктәбен тәмамлый (1911). 1911–13 елларда Уфа губернасында авыл мәктәпләрендә укыта, шушы ук вакытта «Уфимский вестник» (Сухой псевдонимы б-н), «Тормыш», «Мусульманская газета» (Көлкебаш псевдонимы б-н) г-таларында, «Народный учитель» (Сын народа, Учитель татарин псевдонимнары б-н) ж-лында милли мәктәпләр үсеше мәсьәләләрен яктырткан мәкаләләрен, үзенең шигырьләрен, рус һәм чит ил язучыларының әсәрләрен тәрҗемә итеп бастыра. 1913–14 тә Эстәрлетамак өязендә татар социалистлары оешмасы әгъзаларының берсе. Оешма Уфа губернасының халкы арасында агитация эше алып бара. 1915–17 дә Бакуда яши, «Баку», «Кавказское слово», «Кавказская копейка» (Он, Кармаскалинец псевдонимнары б-н) г-талары б-н хезмәттәшлек итә, алар өчен мөселманнар тормышыннан күзәтүләр әзерли. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Милли Шура башкарма ком-ты рәисе Ә.Цаликов чакыруы б-н Петроградка килә һәм әлеге оешманың башкарма ком-ты секретаре итеп билгеләнә. Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтаен оештыручыларның берсе (Казан, 1917 нең июль–августы). Корылтай үз эшчәнлеген




М.Х. Солтангалиев.

тәмамлагач, М.М.Вахитов тәкъдиме б-н С. Казанда кала һәм *Казан Мөселман социалистлар комитетын* оештыруда һәм аның эшчәнлегендә катнаша. 1917 нең июненнән РСДРП(б) әгъзасы, Казанда 1917 елгы Окт. кораллы күтәрелешендә актив катнаша. Идел-Урал штаты оештыру идеясенә каршы чыга, 1918 нең февраль–март айларында «Болак арты республикасы» эшчәнлеге вакытында аның органнары юк итүдә катнаша, Казанда *Революция штабы* составына керә. *Идел-Урал штаты* турындагы Нигезләмәгә каршы куелган *Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасы* турындагы Нигезләмә тарафдары. 1918 нең июль–август айларында *«Красное знамя»* г-тасында (Тамерлан, Кантимер һ.б. псевдонимнар б-н) күпчелек мәкаләләрнең мөхәррире һәм авторы. Мәкаләләрендә Татар-башкорт Респ-касын оештырырга кирәклеген аңлата, контррев-ция тарафдарлары булган сул эсерлардан аерылырга өнди. Мөселман социалистлар ком-тының хәрби секциясен җитәкли, мөселман хәрби частьларын оештыруда катнаша. Гражданнар сугышы елларында В.И.Ленин һәм И.В.Сталин кушуы буенча Ә.Вәлиди б-н башкорт хәрби частьларының Совет хакимияте ягына күчүе һәм Уфадагы сул эсерлар төркеменең большевиклар партиясенә керүе турында сөйләшүләр алып бара. 1919 ның яз-җәендә Көнчыгыш фронтның Революцион хәрби советы әгъзасы, адмирал А.В.Колчак гаскәрләренә каршы сугышларда катнаша. 1919 ның августыннан Мәскәүдә: РСФСР Милләтләр эшләре халык комис-ты коллегиясе әгъзасы, Үзәк мөселман комис-ты рәисе (М.Вахитов һәлак булганнан соң), РСФСР хәрби һәм диңгез эшләре халык комис-ты каршындагы Үзәк мөселман хәрби коллегиясе рәисе, РКП(б) ҮК каршындагы Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы җитәкчесе, Федераль җир эшләре ком-ты рәисе. Башкорт автономиясе вәкилләре б-н сөйләшүләрдә катнаша, Башкорт Респ-касы барлыкка килүне хуплый. РСФСР ХКСның респ-ка оештыру мәсьәләсе буенча материаллар эшләү комиссиясе әгъзасы буларак, Татарстан АССР барлыкка килү турындагы Декрет проектын төзүдә катнаша. 1920, 1922 дә ТАССР ҮБК составына сайлана. Милли мәсьәләне хәл итүдә партия җитәкчелеге карашларына, РКП(б) һәм Совет дәүләте милли сәясәтенең кайбер аспектларына, И.В.Сталинның респ-каларны автономияләштерү планына каршы чыга. СССР оештыруга әзерлек барган чорда милләтләрнең рангларга («улларга һәм үги улларга») бүленешенә каршы чыга, автономияле респ-каларның статусын күтәрүне, аларга СССР субъектлары булу хокукы бирелүне яклый, РСФСР һәм Кавказ арты Совет Федератив Социалистик Республикасы автономияле респ-каларының СССР составына

турыдан-туры кертелүен, автономияле респ-каларның вәкаләтле вәкилләрен СССР ҮБК һәм ХКСна кертү кирәклеген таләп итеп куя. РСФСР Советларының 10 нчы съездындагы тәнкыйди чыгышларыннан соң, И.В.Сталин күрсәтмәсе б-н С.кә карата аның исемен каралта торган материал туплана. 1923 нең 4 маенда ул милли мәсьәләдә партия җитәкчелеге сәясәтенә каршы булган милләтчеләр оешмасы төзүдә гаепләнеп кулга алына. Милли сәясәтне гамәлгә ашыру мәсьәләләренә багышланган *РКП(б) ҮКның дүртенче киңәшмәсендә* (Мәскәү, 1923 нең 9–12 июне) С. һәм аның фикердәшләренең карашлары кискен тәнкыйтьләнә һәм алар «милли тайпылыш тарафдарлары» дип бәяләнә. С. барлык эш урыннарыннан алынып, партиянең һәм Совет дәүләтенең дошманы дип игълан ителә (к. *«Солтангалиевчелек»*). Киңәшмәдән соң ирекkә чыгарыла. 1923–28 дә СССР Сәүдә-кооперация системасында эшли. 1928 дә «максаты СССРны таркату булган милләтче оешма» җитәкчесе буларак кулга алына, 1930 да ОГПУ коллегиясе аны һәм милли респ-каларның кайбер башка җитәкчеләрен атарга хөкем итә (Соловки утравындагы төрмәгә утырту б-н алыштырыла). 1934 тә ирекkә чыккач, Саратов шәһәрендә яши. 1937 нең мартында кабат кулга алына, 1940 ның гыйнвары ахырында СССР Югары мәхкәмәсенең хәрби коллегиясе карары б-н атып үтерелә. 1991 дә аклана.

С.нең теоретик мирасында төп урынны милли мәсьәләне хәл итү идеяләре алып тора (төп нигезләмәләре Мәскәүдә чыга торган «Жизнь национальностей» ж-лында басылган мәкаләләрдә бәян ителә). Аның фикеренчә, антиколониаль хәрәкәтләрнең төп көчен Көнбатыштагы кебек пролетариат түгел, ә барлык демократик көчләрнең берлеге тәшкил итә. Аның казанышлары нәтиҗәсендә халык демократик режимы урнаштырылырга мөмкин, аннан соң гына иҗтимагый-сәяси үсештә соц. этап башлана ала. «Азия һәм Европа төрки халыкларының социаль-сәяси, икътисади һәм мәдәни үсеше нигезләре турында тезислар» («Тезисы об основах социально-политического, экономического и культурного развития тюркских народов Азии и Европы», 1924) хезмәтендә С. марксизмның пролетариат диктатурасы турындагы Нигезләмәсен тәнкыйтьләп, колониаль халыклар өчен ул бары тик капиталистик Европага буйсыну варианты гына булачак дип раслый. Шәрекънең революцион-демократик көчләре берләшүнең төп максаты — антиколониаль рев-ция дип, беренчеләрдән булып ул ассызыклый. С. соц. идеология һәм мөселман җәмгыятенең гореф-гадәтләрен һәм берлеген саклау идеяләре арасында компромисс табарга тырыша. Шәрекъ халыкларын социализмнан читләштермәс өчен, аларның милли һәм дини гореф-гадәтләренә, хисләренә, мәдәниятенә һәм рухи тормышына ихтирамлы булырга; дингә каршы эшне татар, башкорт һ.б. мөселман халыкларының психологиясен һәм көнкүреше үзенчәлекләрен исәптә тотып алып барырга өнди. «Татарлар һәм Октябрь революциясе» («Татары и Октябрьская революция», 1921), «Татар автономияле республикасы» («Татарская автономная республика», 1923) мәкаләләрендә татарларның рев-циядә катнашу тарихының чорларга бүленешен бирә, Татарстанның социаль-икътисади, иҗтимагый-сәяси хәлен тасвирлый. СССР төзелүне халыклары хокуксыз булган Россия империясенең кабат торгызылуы дип саный һәм 1920 елларда ук аның таркалуын фаразлый.

С. идеяләре империализмга каршы хәрәкәтләрнең идеологиясен булдырганда һәм мөстәкыйль дәүләтләр төзү практикасы барышында Азия һәм Африка мөселман дәүләтләрендә популяр була. 1920 еллар башында



М.Х.Солтангалиев (унда) РСФСР Милләтләр эшләре халык комиссариатының кече коллегиясе әгъзалары арасында.

Шәрекъ хезмәт ияләренең коммунистик ун-тында укыткан чорда С.нең 3 нче Интернационал җитәкчеләре, күренекле чит ил дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре С.Катаяма (Япония), Т.Малака (Индонезия), Лю Шаоци (Кытай), Хо Ши Мин (Вьетнам) һ.б. б-н очрашулар вакытында фикерләрен бәян итәргә мөмкинлеге була. А.Беннигсен, Ш.Лемерсье-Келькеже, М.Ямаучи, М.Родинсон һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә Шәрекътә революцион хәрәкәт, җимерелгән колониаль империяләр урынында милли-дәүләт төзелеше мәсьәләләре анализында С.нең роле ачыла. Чит илләр политологиясендә С. «өченче дөньяның революция атасы» буларак танылга.

Чыг.: Тайны национальной политики ЦК РКП: Стеногр. отчёт секретного заседания ЦК ВКП(б). М., 1992; Неизвестный Султан-Галиев: Рассекреченные документы и материалы. К., 2002.

Х е з м.: Избр. труды. К., 1998; Articles. Oxf., 1984.

*Әд.:* С а г а д е е в А.В. Мирсаит Султан-Галиев и идеология национально-освободительного движения. М., 1990; С у л т а н б е к о в Б.Ф. Первая жертва генсека: Мирсаид Султан-Галиев: Судьба. Люди. Время. К., 1991; Б е н н и г с е н А., Л е м е р с ь е - К е л ь к е ж е Ш. Султан-Галиев — отец революции третьего мира // Татарстан. 1993. № 2, 6; Л а н д а Р.Г. Мирсаид Султан-Галиев // Вопр. истории. 1999. № 8; K a y m a k E. Sultan Galiev Ve Somurgeler Enternasyonali. Ist., 1993; Y a m a u c h i M. Islam and Russia. Sultangaliev Revisited. Tokio, 1995.

*Б.Ф.Солтанбәков.*

**«СОЛТАНГАЛИ́ЕВЧЕЛӘРНЕҢ МӘСКӘ́Ү ҮЗӘГЕ́» ЭШЕ́** («Оештыручы үзәк»). 1932 елда ОГПУ-НКВД органнары тарафыннан шактый кешеләргә карата оештырылган гаепләү эше. Алар Солтангалиевнең контрреволюцион оешмасы б-н элемтә урнаштыруда, гарәп графикасыннан латин графикасына күчүгә каршы булган чыгышлар оештыруда (*«Сиксән икеләр хаты»*), интеллигенция, эшчеләр һәм крәстияннәр арасында контрреволюцион милләтчелек идеяләре таратуда, ВКП(б) һәм Совет хөкүмәтенең хуҗалык һәм сәяси чаралары үтәлешенә комачаулауда, авылда массакүләм чыгышлар оештыруда, колхоз милкен яндыруда, хакимият әһелләренә каршы террорлык актлары әзерләүдә, татар буржуаз-милләтчелек оешмаларын (Мөселманнар ком-ты, Хәрби Шура, Милли Шура, Милли Сәрмая) төзүдә катнашуда, 1922–23 тә Совет хакимияте эшчәнлегенә каршы программалы-тактик принциплар каралган «медполислар», ягъни легаль булмаган киңәшмәләр оештыруда гаепләнә. Оешманың Татарстан ф-лы эше буенча 18 кеше, ш.и. И.С.Аитов, Ш.Ш.Әхмәров, И.Җ.*Бикколов*, Җ.*Вәлиди*, С.Х.Вәлидов, Л.Ш.Вахитов, Х.В.Зәбиров, Ю.С.Латыйпов, А.А.Шаехгали тикшерү уза. Мәхкәмә утырышы 1932 нең 11 маенда Казанда үтә. ОГПУ хәрби коллегиясе тарафыннан Җ.Вәлиди һәм Х.В.Зәбировтан кала барлык гаепләнүчеләр дә төрле елларга (3 елдан алып 5 елга кадәр) хөкем ителәләр. 1989 һәм 1990 елларда СССР ЮС Президиумы карарлары б-н гаепләнүчеләр аклана һәм, «кылган гамәлләрендә җинаятьчелек составы булмау сәбәпле», эш туктатыла.

**«СОЛТАНГАЛИ́ЕВЧЕЛЕК»**, 1920–30 елларда СССРда татар һәм башкорт партия, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләренә «милли тайпылышта» гаепләп тагылган сәяси ярлык. «С.» төшенчәсе совет сәясәт һәм дәүләт эшлеклесе М.Х.*Солтангалиевнең* эшен тикшерү барышында таралыш ала. Беренче мәртәбә *РКП(б) ҮКның дүртенче киңәшмәсендә* илдәге милли сәясәт мәсьәләләренә караган материалларда кулланыла. Партия документларында һәм пропаганда материалларында «С.» совет хөкүмәтенә каршы оештырылган, партия сыйфатларына да ия хәрәкәт буларак күзаллана. «С.» турындагы эш ОГПУ тарафыннан СССРның милли регионнарында бу мәсьәләдә башкача фикерләүгә каршы көрәшне җиңеләйтү өчен оештырыла. 1930 елларда кешене «С.»тә гаепләү аны репрессияләү өчен гадәти сәбәпкә әверелә. М.Х.Солтангалиев һәм «С.»тә гаепләнгән башкалар бары 1990 елларда гына аклана. Ш.у.к. *«Солтангалиевчеләрнең Мәскәү үзәге» эше*.

(Чыганакларны һәм әдәбиятны М.Х.*Солтангалиев* мәкаләсеннән кара).

*Б.Ф.Солтанбәков.*

**СОЛТА́НОВ** Әлфәт Сәлим улы (10.1.1950, Мамадыш р-ны Игенче а.), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007), РФнең атказ. геологы (2010), техник фән. кандидаты (2006). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1973), «Якутскгеология» берләшмәсендә инженер, өлкән инженер, отряд, партия башлыгы булып эшли. 1981 елдан «Татнефть» АҖдә: геолог, цех өлкән геологы, геол., технол. бүлекләре башлыгы, «Җәлилнефть» НГДУында баш геолог урынбасары (2000 гә кадәр), АҖнең нефть чыганакларын эшкәртү б-н идарә итү бүлеге башлыгы (2002–03, 2006 дан), «Нурлатнефть» НГДУы баш геологы (2003–06). Уйлап табуга 4 авторлык



Закир Солтанов.



З.Г.Солтанов.

таныклыгы бар. Дәүләт бүләге автоматлаштырылган проектлау технологияләре нигезендә нефть чыганакларын эшкәртү б-н идарә итү алымнарын булдырганы һәм сәнгатьтә кулланышка кертгәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Опыт геологического обоснования бурения горизонтальных скважин // Нефтяное хоз-во. 2004. № 7 (автордаш); Особенности разработки залежей нефти терригенных и карбонатных коллекторов месторождений НГДУ «Нурлатнефть» // шунда ук. (автордаш); Методы уточнения геологической модели разреза по данным горизонтальных скважин // Нефтепромысловое дело. 2005. № 8 (автордаш).

**СОЛТА́НОВ** Вәсим (Мөхәммәтвәсим) Мөхәммәтзариф улы (22.8.1887, Уфа губ., Бөре өязе Шабай а. — 1977, Сәмәрканд ш.), язучы. 1903 елда «Госмания», соңрак «Галия» мәдрәсәсендә белем ала (1909 да шәкертләр хәрәкәтендә катнашканы өчен куыла). 1910 нан соң Бөре шәһәрендә татар мәктәбендә укыта. 1911–14 тә Казан татар укытучылар мәктәбендә укый. Аны тәмамлаганнан соң, Благовещенск, Чита шәһәрләрендә рус-татар мәктәпләрендә укыта. 1916–17 дә Уфа губернасы Эстәрлетамак өязе Бозауяз авылы китапханәсе мөдире. 1917–23 елларда Читада яши, рус-татар мәктәбендә укыта, татар җәмгыяте эшчәнлегендә актив катнаша. 1924 тә Үзбәкстанга күчә, Сәмәрканд, Бохара уку йортларында эшли. «Канау буенда» (1909), «Ләззәт, яки Тәм» (1909) шигырь җыентыклары, хикәяләр, публицистик мәкаләләр авторы. 1938–46, 1949–55 тә репрессияләнә.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М. Татар әдәбияты тарихында яңа исемнәр // Мәгърифәт һәм азатлык өчен көрәш. К., 1987; Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Библиогр. сүзлек. К., 2005.

**СОЛТА́НОВ** Закир (29.6.1923, хәзер Удмурт Респ-касының Кече Пурга р-ны Әбделмән а. — 6.4.1983, Украина ССР, Херсон ш.), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), лейтенант. ФЗӨ (1940), Эчке эшләр министрлыгының Куйбышев офицерлар составы мәктәбен (1947) тәмамлый. Ижевск машина төзелеше з-дында слесарь булып эшли. 1942 елның ноябреннән Кызыл Армиядә. 1943 нең гыйнварыннан Бөек Ватан сугышында, 498 нче укчы полкның (47 нче армиянең 132 нче укчы дивизиясе) танкка ата торган мылтык взводы командиры. 1 нче Украина, 2 нче Белоруссия һәм 1 нче Белоруссия фронтлары составында Сулъяк яр Украинаны азат итүдә (1943), Люблин-Брест (1944) һәм Көнчыгыш Померания (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Яблонно-Легионово шәһәреннән (хәзер Легьоново ш., Польша) төньяктарак булган сугышларда батырлык күрсәтә: 1945 нең 15 гыйнварында С. җитәкчелегендәге взвод дошманның оборона сызыгын өзүдә катнаша, Чонсткув торак пункты янында Висла елгасын кичеп чыга һәм батальон килеп җиткәнче позицияне үз кулында тота. 1947–53 тә Свердловск шәһәрендә һәм Свердловск өлкәсендә оператив вәкил булып эшли. 1953 тән запаста, Херсон шәһәрендә яши. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.


*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СОЛТА́НОВ** Зәйни (чын фамилиясе һәм исеме Сөләйманов Зәйнелгабидин) Гобәйдулла улы (17.1.1892, Әстерхан ш. — 5.5.1952, Казан), драма актёры, режиссёр, педагог, театр эшлеклесе, язучы-тәрҗемәче, ТАССРның халык (1939), РСФСРның атказ. (1940) артисты. Әстерхан шәһәрендәге татар проф. театрына нигез салучыларның берсе. Әстерханда «Ак мәчет» мәктәбендә, Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. 1907 елда Әстерханда И.Гыйззәтуллин-Дубровин җитәкчелегендәге татар театр труппасына керә, 1908 дә Г.Кариев һәм Г.Араблинский б-н гастрольләргә килгән «Сәйяр» труппасы спектакльләрендә катнаша. 1914 тә, «Татар драма артистлары ширкәте»н оештырып, Әстерхан труппасы б-н җитәкчелек итә, бер үк вакытта актёр, режиссёр һәм ширкәт башлыгы була. 1918 дә *Әстерхан татар драма театры* каршында *Әстерхан татар театр студиясен* оештыра. 1920–21 дә К.Тинчурин һәм И.Рәмиев б-н бергә *Самара татар драма һәм музыка студиясен* төзи. 1922 дән Казанда Татар дәүләт драма театрында; ТАССР Мәгариф халык комис-ты карары йөкләмәсе буенча Татар театр техникумын оештыру б-н шөгыльләнә (Казан Зур драма театры каршындагы студия педагогы һәм актриса З.М.Славянова б-н бергә). 1923–25 тә Әстерхан татар драма театрының сәнгать җитәкчесе. 1925 тән Казанда Татар акад. театры труппасында. Труппаның әйдәп баручы актёрларыннан берсе, тамашачының югары бәясенә лаек булган рольләр иҗат итә. Аеруча зур рольләре арасында Кәрим бай, Хәмзә бай, Сираҗетдин («Бәхетсез егет», «Беренче театр», «Банкрот», Г.Камал), Мисбах хаҗи, Ишан («Җилкәнсезләр», «Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Надир шаһ (Н.Наримановның шул исем. әсәре буенча), Иманкол мулла («Наёмщик», Т.Гыйззәт), Юныс хаҗи («Хаҗи әфәнде өйләнә», Ш.Камал), Хөсәен мирза (Ф.Бурнашның шул исем. әсәре буенча), Әҗим («Мулланур Вахитов», Н.Исәнбәт), Кречинский («Кречинскийның туе», А.В.Сухово-Кобылин), Нил, Лука («Мещаннар», «Тормыш төбендә», М.Горький), Берсенев («Разлом», Б.А.Лавренёв) һ.б. була. Көчле театральлек, социаль үткенлек С. иҗат иткән образларга зур масштаб һәм тулылык бирә, актёрның һәр чыгышы театр тормышында зур вакыйга буларак кабул ителә. Режиссёр буларак, Татар акад. театры сәхнәсендә К.Тинчуринның «Ил», М.Җәлилнең «Гудок», А.М.Файконың «Доцент Янбулатов» (барысы да — 1929), В.П.Катаевның «Авангард» (1930), Г.Камалның «Банкрот» (1933) һ.б. әсәрләр буенча спектакльләр куя. Күп кенә пьесаларны татарчага тәрҗемә итә. С.ның иҗади эшчәнлеге татар театры тарихында сизелерлек эз калдыра. Хезмәт Герое (1924).



З.Г. С о л т а н о в Городничий («Ревизор», Н.В.Гоголь) ролендә.



З.Г. С о л т а н о в Кәрим бай («Бәхетсез егет», Г.Камал) ролендә.

*Әд.:* М ә х м у т о в Һ. Әстерханда татар театры // Мирас. 1994. № 1–3, 7–12; 1995. № 1–8; Татар театры (1906–1926). К., 2003; И л я л о в а Н. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала: Биогр. белешмәлек. К., 2005; ш у л у к. Театр имени Г.Камала. К., 1986.

*И.И.Илялова.*

**СОЛТА́НОВ** Мансур Ислам улы (1875, Уфа губ., Минзәлә өязе Мәчти а. — 1918, Саратов ш.), флейтачы, педагог. Татарлар арасыннан югары муз. белем алган беренче кеше. Чыгышы б-н морзалар нәселеннән, мөфти М.*Солтановның* туганы. Уфа шәһәрендә гимназия тәмамлый. 1898 елдан Мәскәү консерваториясенең флейта классында укый (тәмамлаган елы билгесез). Симф. оркестрларда уйный, концертларда соло номерлар б-н чыгышлар ясый. 1912 дән флейта һәм кларнет класслары буенча укыта, ш.у. яңадан оешкан Саратов консерваториясендә сольфеджио классы ача. Башкорт һәм татар халык көйләрен җыеп эшкәртә.

Х е з м.: Башкирские и татарские мотивы. Саратов, 1916.

**СОЛТА́НОВ** Мөхәммәдъяр Мөхәммәдшәриф улы (1837 — 12.6.1915, Уфа ш.), дин эшлеклесе. 1856 елда Казан ун-тының юридик ф-тында укый. 1857–59 да *Башкорт-мишәр гаскәрендә* хезмәт итә, 1861–66 да Уфа губернасының 20 нче һәм 7 нче кантоннар башлыгы. 1866–85 тә Уфа губернасындагы Минзәлә һәм Бәләбәй өязләрендә арадашчы казый, җәмәгать казые вазифаларын башкара. 1886 дан Оренбург Мөселман Диния нәзарә-

те мөфтие. С. вакытында Диния нәзарәте эшчәнлеге яңача оештырыла: 1889 дан мөфти казый сайлауда катнашу хокукы ала, нәтиҗәдә төрле вакытта казый вазифасына, С. тәкъдиме б-н, күренекле татар мәгърифәтчеләре Р.*Фәхретдин*, Х.Г.*Габәши*, Р.*Ибраһимов* сайланып куела. 1893 тә хаҗ кыла; Россия мөселманнарының рәсми вәкиле буларак, төрек солтаны Габдел-Хәмид II (1876–1909) тарафыннан кабул ителә, төрек ордены б-н бүләкләнә. С. булышлыгы б-н Уфада «Галия» мәдрәсәсе ачыла (1906). «Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Ырынбургия» ж-лына нигез салучыларның берсе (1908). Илаһият белеме булмау сәбәпле, мөселманнарның мәнфәгатьләрен яклауда эзлексезлеге нәтиҗәсендә кадимчеләр һәм җәдитчеләр вәкилләре тарафыннан тәнкыйтьләнә. I дәрәҗә Изге Анна, I дәрәҗә Изге Станислав орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Хабутдинов А.Ю. Российские муфтии: от екатерининских орлов до ядерной эпохи (1788–1950). Н.Новгород, 2006.

**СОЛТА́НОВ** Наил Зәки улы (12.9.1953, Үзбәкстан ССРның Сәмәрканд ш.), катлаулы системаларны модельләштерү һәм нәтиҗәләлеген тикшерү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1997), проф. (1998). 1976 елда Ташкент политехник ин-тын тәмамлаганнан соң, В.П.Чкалов исем. авиация ҖБдә (Ташкент ш.) эшли. 1984–95 тә Ташкент политехник ин-тында. 1995 тән Оренбург ун-тында, инновацион проектлар б-н идарә итү каф. мөдире (1997–99), каф. профессоры (1999 дан), Икътисад ин-тының инноватика ф-ты деканы (1999–2000), баш гыйльми секретарь (2001–04). 2004 тән Аэрокосмос ин-тының җитештерүне автоматлаштыру системалары каф. мөдире. Хезмәтләре техник, икътисади һәм оештыру системаларын модельләштерүгә һәм аларның нәтиҗәлелеген тикшерүгә карый. Авиация сәнәгате пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән 4 проект авторы («Грач» тәҗрибә экранопланы; БС-1 самолётының штопор һәм флаттер модельләре; аэрофототөшерү өчен телевизион идарә ителүле мини-самолёт; а.х. самолётлары һәм вертолётлары өчен җиһазлар комплексы). Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсы медальләре б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2003).

Хезм.: О построении модели исследования воздушно-транспортной системы для перевозки нефти и газа // Изв. вузов. Авиац. техника. 1980. № 4; Механика конструкций из композиционных материалов. Таш., 1990 (автордаш); Инновационные процессы в авиационно-химических работах: экологический аспект. Оренбург, 1998 (автордаш).

**СОЛТА́НОВ** Сәгъди Әхмәди улы (15.3.1922, Уфа губ. Яңа Гали а. – 1992, Уфа ш.), геолог-геофизик, геол.-минерал. фән. д-ры (1964), проф. (1969), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1973), СССРның мактаулы нефтьчесе (1975). Мәскәү нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), ТатНИИнефтьтә эшли, директор урынбасары (1963 тән). 1983 елдан Уфа нефть ин-тында. Хезмәтләре нефть чыганакларын разведкалау һәм эшкәртүгә карый. С. нефть чыганакларын эшкәртү һәм аларны көйләү процессларын тикшерү буенча яңа фәнни юнәлеш тәкъдим итә. СССР Дәүләт бүләге (1978), СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге (1982) лауреаты.

**СОЛТА́НОВ** Фәрит Мирза улы (25.8.1951, Яшел Үзән р-ны Олы Карагуҗа а.), философ, филос. фән. д-ры (2000), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (2002). Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлаганнан соң (1974), ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында эшли, 1985 елдан иҗтимагый фикер тарихы секторы мөдире, 1993 тән РФ Мәгариф министрлыгы Милли проблемалар ин-тының Татарстан ф-лы мөдире. 1996 дан ТР ФАнең Тарих ин-ты директоры урынбасары, бер үк вакытта ин-тның Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге җитәкчесе. 2012 дән ТР ФА президиумы аппаратында: баш белгеч, ТР ФА президентының гомуми эшләр буенча урынбасары, гомуми эшләр идарәчесе. 2016 дан Казан ун-тында. Хезмәтләре татар иҗтимагый фикере тарихына, ислам факторына, татар милли хәрәкәтенә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Хөр фикер юлында. К., 1986; Ислам и татарское национальное движение в российском и мировом мусульманском контексте. К., 1999; Татарское национальное движение: История и современность. К., 2000.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. 2004. Т. 3.

**СОЛТА́НОВ** Фуат Фәйзерахман улы (30.3.1928, Төрекмәнстан ССР, Ташауз ш. — 2003, Ашхабад), патофизиолог, мед. фән. д-ры (1965), Төрекмәнстан ССР ФА академигы (1975). Төрекмән мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), шунда ук эшли, 1960–63 елларда патофизиол. каф. мөдире вазифаларын башкаручы, бер үк вакытта табибләр белемен күтәрү ф-ты деканы. 1964 тән СССР МФАнең Төрекмән төбәк медицинасы ин-тында физиол. секторы мөдире, проф. (1967), Төрекмәнстан ССР ФА вице-президенты (1989). Хезмәтләре кеше һәм хайваннарның җылылык алмашын, арид зона шартларында организмның кискен кызу патофизиологиясе һәм патогенезына карый. Төрекмәнстан ССР Дәүләт бүләге лауреаты. Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Экологические условия пустынь в адаптация организма человека к аридной зоне // Проблемы освоения пустынь. 1985. № 1 (автордаш); Температура тела, конвекционный теплообмен человека при работе в условиях высокой температуры аридной зоны // Физиология человека. 1986. Т. 12, № 6 (автордаш); Развитие физиологических исследований в Туркменистане // Физиол. журн. 1987. Т. 73, № 11.

**СОЛТА́НОВ** Хәтмулла Асылгәрәй улы (20.7.1924, Бәләбәй кантоны, хәзер БРның Бүздәк р-ны Кәпәй-Кыбау а. — 4.3.1994, БРның Кандра штп), Дан орденының тулы кавалеры (21.1.1945, 13.4.1945, 15.5.1946), Соц. Хезмәт Герое (1971), гв. өлкән сержанты. 1938–41 елларда Партизанск шәһәре (Приморье крае) шахтасында эшли. 1941 нең сентябреннән Кызыл Армия сафларында. 1943 нең гыйнварыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 174 нче гв. укчы полкында танкка каршы отделение командиры (8 нче гв. армиясенең 57 нче гв. укчы дивизиясе). Көньяк-Көнбатыш, 3 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Донбасс (1943), Никополь-Криворожск, Белоруссия (икесе дә — 1944) һәм Берлин (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша.




Х.А.Солтанов.


1945 нең 15 гыйнварында Грабна-Воля торак пунктыннан (Едлинск шәһәреннән 22 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Польша) төньяктарак дошман контрһөҗүмен кире кайтарганда батырлык күрсәтә: шәхсән үзе берничә солдатны юк итә һәм отделениесе б-н яуланган чикне тотып тора; 1945 нең 2 мартында Ратшток торак пункты (Зеелов шәһәреннән 11 *км* көнчыгыштарак, Германия) өчен сугышта, төн караңгылыгыннан файдаланып, сугышчылар б-н дошман тылына үтеп керә, 8 солдатны юк итә, берсен әсир ала; 1945 нең 14 апрелендә Альт-Тухебанд торак пункты (Зеелов шәһәреннән 8 *км* көнчыгыштарак) өчен сугышта беренчеләрдән булып торак пунктка бәреп керә, дошманның 3 пулемётын кулга төшерә, 4 солдатын әсир ала, яралана, әмма сафта кала. 1946 да демобилизацияләнгәннән соң, туган авылында «Кыдаш» к-зында эшли. 1948–89 да Туймазыда «Башнефть» җитештерү берләшмәсенең бораулау эшләре идарәсендә эшче, бораулаучы ярдәмчесе, бораулаучы (1950 дән), бораулаучы оста (1970 тән). С. вахтасы Башкортстан бораулаучылары арасында беренчеләрдән булып бригадага елына 20–21 мең *м* җир бораулау өчен ярышны башлап җибәрүче. 1970 тә С. вахтасы, 6310 *м* тау токымын бораулап, йөкләмәне уңышлы үти, идарәнең бораулау бригадалары арасында иң югары күрсәткечкә ирешә; идарәдә ул беренчеләрдән булып разведка скважиналарын бораулаганда махсус сыекча б-н юдырткыч, аз балчыклы эретмәләр, махсус майлагыч матдәләр, җиңел металлардан ясалган бораулау торбаларын куллана, бу аңа бишьеллык эчендә коммерция тизлеген бер станокка аена — 967 *м* дан (1965) 2000 *м* га (1970), җитештерү вакытын 71,5 % тан — 79 % ка кадәр арттырырга мөмкинлек бирә. Бригада башкарган норматив йөкләмә 120–124 % тәшкил итә; 5 елга 63,4 мең сум акча экономияләнә. С. Дәүләкән, Михайлов, Добровольск нефть чыганакларын ачуда катнаша.

Герой исеме нефть чыгару һәм нефть сәнәгатен үстерүдәге, яңа нефть-газ урыннарын разведкалаудагы хезмәтләре, бишьеллык планны (1966–70) уңышлы үтәгәне өчен бирелә. 1974–89 елларда СССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Хәлим А. Минем Түгәрәк Иманем. Уфа, 1999; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000; Хакимов М.С.,



Һ.Һ. Солтанов.




Л.М. Солтанова.

С а ф а р о в М.А. Татары: воины, труженики, патриоты. М., 2006.

*М.З.Хәбибуллин, М.Я.Гаитов.*

**СОЛТА́НОВ** Һидаят Һидиятулла (Айниятулла) улы (30.11.1915, Сембер губ., Буа өязе Татар Убие а. — 9.11.2009, Казан), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1972). 1937 дән, Казан сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлаганнан соң, Ташкент татар театрында эшли. 1940 тан БАССРның Яңавыл татар театрында. 1947 дән Татар акад. театры актёры, 1991 дән «Инсаният» труппасында. С., күппланлы характерлы актёр буларак, сәхнәдә гадилекләре, табигыйлекләре һәм төгәл тышкы формалары б-н аерылып торган шактый гына рольләр башкара. Аеруча зур рольләре арасында Исмәгыйль («Галиябану», М.Фәйзи), Әскәр («Аршин мал алан», У.Хаҗибәков), Рамай («Шәмсекамәр», М.Әблиев), Әҗим («Мулланур Вахитов», Н.Исәнбәт), Потёмкин («Пугачёв Казанда», Ә.Фәйзи; «Канкай углы Бәхтияр», Т.Миңнуллин), Артамонов («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Җиһанша («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Газизов, Евстигней («Монда тудык, монда үстек», «Әлдермештән Әлмәндәр», Т.Миңнуллин), Арсланов («Намус хөкеме», Д.Вәлиев), Баһрам («Шәһәрдә җәй көннәре», Анар), Нурәхмәт («Китәм инде», Р.Хәмид), Вурм («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), Эдмунд («Король Лир», У.Шекспир), Лещ («Соңгылар», М.Горький) һ.б. бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Һ.Һ. С о л т а н о в Алмас ролендә («Моңлы бер җыр», Т. Миңнуллин; уңда – Шагыйрь ролендә И. Хәйруллин).

*Әд.:* И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала: Биогр. белешмәлек. К., 2005; ш у л у к. Театр имени Камала. К., 1986.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**СОЛТА́НОВА** Галия (Гилә) Фазыл кызы (2.12.1928, Мамадыш кантоны Кукмара а. — 11.10.2007, Чабаксар), педиатр, мед. фән. д-ры (1970), проф. (1971). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), шунда ук госпиталь педиатриясе кафедрасында эшли. 1953 елдан Тува АССРның Кызыл шәһәрендәге өлкә хастаханәсендә балалар туберкулёзы бүлеге мөдире. 1959 дан Свердловск шәһәрендәге Аналар һәм балалар сәламәтлеген саклау фәнни-тикшеренү ин-тында. 1967 дән — Казан ГИДУВының 2 нче педиатрия, 1970 тән 1 нче педиатрия кафедралары мөдире. 1977 дән Чуаш ун-тының педиатрия каф. мөдире. Хезмәтләре туберкулёз, лейкоз, яшь балалар организмында тимер җитмәү анемиясе мәсьәләләренә карый. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Анемия недоношенных детей. К., 1978.
*Әд.:* Профессор Султанова Г.Ф. // Казан. мед. журн. 1989. № 1.

**СОЛТА́НОВА** Луиза Миргазиян кызы (18.1.1944, Азнакай р-ны Банки Сукаеш а.), драма актрисасы, ТАССРның халык артисты (1981). Сәхнә эшчәнлеген Лениногорск төзелеш-монтаж идарәсенең үзешчән сәнгать коллективында башлап җибәрә, М.Фәйзинең «Галиябану» пьесасы буенча куелган спектакльдә Галиябану ролен башкара. 1962 елда Әлмәт татар драма театрына чакырып алына, анда Гөләндәм, Гандәлиф («Яланаяклы кыз», «Көзге ачы җилләрдә» А.Гыйләҗев), Гөлчирә («Ташкыннар», Т.Гыйззәт) рольләрен уйный. 1964–66 да реж. Г.Йосыпов җитәкчелегендәге театр каршында урнашкан студиядә укый, бер үк вакытта спектакльләрдә катнашуын дәвам итә. Хәмдия («Ак калфак», М.Фәйзи), Шәфәкъ («Ай тотылган төндә», М.Кәрим), Мәйсәрә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Ольга («Ябырылу», Л.М.Леонов) рольләрен башкара. Табигатьтән бирелгән сәләте, сәхнәдәге мөлаемлыгы, башкарган рольләренең хис-кичерешләргә байлыгы, аларның эшләнешендә нечкә психологизм С.га танылу китерә һәм тамашачы мәхәббәтен яулый. Киң диапазонлы актриса буларак, С. трагедия һәм комедия рольләрен дә башкара: Баянсылу («Кузы Күрпәч белән Баянсылу», Г.Мөсрәпов), Җәмилә («Бай һәм батрак», Хәмзә), Алиман («Анам кыры», Ч.Айтматов), Зөһрә, Сәрби («Таһир-Зөһрә», «Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), Шәмсекамәр (М.Әблиевнең шул исем. әсәре буенча), Расиха («Әни килде», Ш.Хөсәенов), Диләфрүз, Дания («Диләфрүзгә дүрт кияү», «Ай булмаса, йолдыз бар», Т.Миңнуллин), Рашель («Васса Железнова», М.Горький) һ.б. образларны иҗат итә. С. тудырган образлар, хатын-кызларга хас булганча, йомшаклык, мөлаемлык б-н сугарылган һәм бер үк вакытта хатын-кыз күңеленең поэтик фидакарьлеген гәүдәләндерүче характер бөтенлеге б-н дә аерылып тора.



Л.М. С о л т а н о в а Мәстүрә ролендә («Җырланмаган җыр», М.Кәрим; Дусмәт Ярлыкапов ролендә — К. Вәлиев).

*Д.Ә.Гыймранова.*

**СОЛТА́НОВА-ЖДА́НОВА** Фирая Рифкать кызы (29.4.1961, Актаныш р-ны Түке а.), спортчы (җиңел атлетика), ТРның (2003), Россиянең (2004) атказ. спорт остасы. Әлмәт физик культура техникумын (1979), Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лын (1983) тәмамлый. Спорт б-н 1976 елда «Спартак» ирекле спорт җәмгыятендә шөгыльләнә башлый, тренерлары — В.И.Осетрин, М.Н.Чинкин, Г.В.Цыганов, В.М.Жданов (1995 тән). 1986–2003 тә СССР, Россия җыелма командалары әгъзасы. 1983–2008 дә «КАМАЗ» АҖдә, 2008 дән «Чаллы» олимпия резервы махсус балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (Чаллы ш.) спорт буенча инструктор. РСФСР (1987, 1500 *м* га йөгерүдә), Россия чемпионатларында (1996, 20 *км* га шоссе буенча йөгерүдә), халыкара йөгерүдә (1996, 10 *км* га шоссе буенча йөгерүдә), халыкара марафонда (1999, 2003, 2004), АКШ ачык чемпионатында (2004, 25 *км* га йөгерүдә, ветераннар арасында) җиңүче. СССР Кубогы (1987, 100 *м* га йөгерүдә), Суперкубок (1996) иясе. Россия чемпионатында (1998, ярым марафон), АКШ ачык чемпионатында (2004, 25 *км* га йөгерүдә), Дөнья кубогында (1995, команда зачётында) көмеш приз ала; СССР (1986, крос), Россия (1994, 20 *км* га шоссе буенча йөгерүдә), социалистик илләр кроссында (1987), бертуган Знаменскийлар мемориалында (1988), Дөнья кубогында (1998, 2001, команда зачётында) бронза медаль ала. АКШта марафон трассасы рекордчысы (2002, 2004, ветераннар арасында). Олимпия уеннарында катнаша (1996). Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (2006). 2004 тән АКШта яши.

**СОЛТА́НОВЛАР**, татар морзалары нәселе. Оренбург губернасының Минзәлә өязе Мәчти авылында яшәгәннәр. 1796 елда Оренбург губернасының морзалар китабына Әбҗәлил (Габделҗәлил) исеме балалары б-н язып куела (балалары арасында — танылган гаскәри старшина Мөхәммәдрәхим һәм майор (1817) Баязит С.). 1859 да отставкадагы сотник (йөзбашы) Шәйхелислам Мөхәммәдрәхим улы Солтановның Оренбург губернасының Бәләбәй өязе Смысловка авылында 22 крепостной крәстияне була; бертуганы Шаһимәрдан б-н бергә Оренбург губернасының Минзәлә өязе Казанчы һәм Яңа Усы авыллары янында 1000 дис. җир били. Баязит Солтановның

оныгы — Оренбург Мөселман Диния нәзарәте мөфтие М.М.*Солтанов*, татарлар арасыннан югары музыкаль белем алган беренче кеше М.И.*Солтанов* та С. нәселеннән.

*Әд.:* Новиков В.А. Сборник материалов для истории уфимского дворянства. Уфа, 1879; Габдуллин И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

**СОЛУЯ́НОВ** Юрий Иванович (25.9.1939, Горький өлкәсенең Починки р-ны Починки а.), сәнәгать пр-тиеләрен һәм җайланмаларын электрлаштыру өлкәсе белгече, техник фән. д-ры (2003), проф. (2005), ТАССРның атказ. төзүчесе, Россиянең мактаулы төзүчесе (1998). 1961 елда Горький политехник ин-тын тәмамлый. «Татэлектромонтаж» трестының Әлмәт (1961–68), Түбән Кама (1968–73), 2 нче Казан (1973–77) монтаж идарәләрендә эшли. 1977 дән «Татэлектромонтаж» АҖдә: баш инженер, управляющий (1982–93), ген. директор (1993 тән). Бер үк вакытта, 1984 тән, Казан энергетика ун-тында, сәнәгать пр-тиеләрен электр б-н тәэмин итү каф. профессоры (1999 дан), тормыш иминлеге каф. мөдире (2004 тән). Хезмәтләре сәнәгать пр-тиеләренең электр куркынычсызлыгына карый. С. җиргә тоташтыру җайланмалары сыйфатында биналарның металл һәм тимер-бетон каркасларын, ш.у. аларның фундаментларын куллану мөмкинлеген күрсәтә (бу хезмәтләре КАМАЗ һәм Түбән Кама нефть химиясе комб-ты төзелешләрендә кулланыла). Пр-тиеләрдәге электр җайланмаларының куркынычсызлыгын тәэмин итүне тикшерә; җиргә тоташтырылган җиһазларның куркынычсызлык чикләрен исәпләү методикасын эшли, электр җайланмаларын урнаштыру буенча күрсәтмәләр бирә (Алабуга автомобиль з-ды, Түбән Кама нефть химиясе комб-ты, Казан органик синтез з-ды объектларында кулланыла). Уйлап табуга 29 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. «Почёт билгесе», Дуслык ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Защитные меры электробезопасности нефтехимических предприятий. К., 2002; Использование строительных конструкций зданий и сооружений в качестве зануляющих устройств. К., 2003; Повышение эффективных защитных мер электробезопасности электроустановок промышленных предприятий. К., 2004.

**СОЛЫ́** (Avena), кыяклылар семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы; бөртекле культура. 25 төре билгеле, Евразия, Төньяк Африкада таралган. С.ны б.э.к. 2 нче йөздә үстерә башлыйлар, Россиядә б.э.ның 7 нче йөзендә, Татарстанда Идел буе Болгар дәүләте вакытыннан билгеле. Чук тамырлы. Сабагы түгәрәк, куыш, биеклеге 1 *м* га кадәр. Яфраклары ланцетсыман, чәчәкләре себеркәч барлыкка китерә торган озын кылчыклы башак формасында. Бөртеге (бөртекчәсе) тәңкәләр б-н әйләндереп алынган. Үз-үзеннән серкәләнә. Июнь–июльдә чәчәк ата. Вегетация чоры 80–110 тәүлек. Иң яхшы туфраклар — кара туфрак, соры урман туфрагы, кәсле-көлсу туфрак. ТРда чәчүле С. (A. soctilva) — төп бөртекле фураж культурасы. Саламын һәм яшел массасын, аеруча вика һәм борчак катнашмасында, терлек азыгы буларак кулланалар. Бөртеген ярма һәм онга эшкәртәләр. С.ны диетик туклану продукты буларак ашказаны-эчәк, буыннар, радикулит, бөер-таш авыруларыннан кулланалар. С.ның 1 *кг* бөртеге туклыклылыгы буенча 1 азык берәмлеге тәшкил итә, анда 87 *г* үзләштерелә торган протеин бар. ТРда үстерелә торган сортлары: «Скакун» (1982), «Друг» (1983), «ЛОС-3» (1991), «Аллюр» (1997). С. чәчүлекләре мәйданы уртача 146,1 мең *га*, уңышы 1 *га* дан 31,4 *ц* (2000–04).

**СОЛЫ́ ЧЫПЧЫКЛАРЫ́** (Emberiza), шул ук семьялыктагы сайрар кошлар ыругы. 40 ка якын төре билгеле, Евразия, Төньяк Америка, Африкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә 8 төре мәгълүм. Гади солы чыпчыгы (E. citrinela), камыш чыпчыгы (E. schoeniclus), ремез чыпчыгы (E. rustica), имәнлек чыпчыгы (E. aureola), бакча солы чыпчыгы (E. hortulana) барлык районнарда да очрый һәм даими оя коручы кошларга керә. Тары чыпчыгы (E. calandra), ак бүрекле солы чыпчыгы (E. leucocephalos), кечкенә солы чыпчыгы (E. pusilla) — сирәк очып керүче төрләре. Болыннарда, аланнарда, сирәкләнгән урманнарның түбән ярусында, үләннәр үскән кисенделәрдә оялый. Гәүдәсе озынча, тыгыз, озынлыгы 5–20 *см*, авырлыгы 23–25 *г*. Каурый капламы куе, йомшак, аркасында һәм койрыгында кара яки аксыл чуар көрән-җирән төс өстенлек итә. Канатлары озын, чагыштырмача очлы. Койрыгы уемтылы. Томшыгы зур түгел, өске һәм аскы читләре бер-берсенә тулысынча утырмыйлар, һәм томшык ябылган вакытта, алар арасында ярык кала. Башка С.ч.ннан ак бүрекле солы чыпчыгы — баш түбәсендәге ак тап, кечкенә солы чыпчыгы башының җирән булуы һәм күз өстендәге кара сызыгы б-н аерыла. С.ч. касәсыман оясын җирдә, түмгәкләр астында, зур булмаган куаклар төбендә кора. Коңгырт, алсу яки шәмәхә төсмерле 4–6 соргылт-ак йомырка сала. Җаен үрмәкүчләр, бөҗәкләр, көзге-кышкы чорда, нигездә, үсемлек орлыклары б-н туклана.

**СОЛЫЧЫ́К**, буш солы (Avena fatua), кыяклылар семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлек; чүп үлән. Евразия, Төньяк Африка, Төньяк Америкада үсә. ТРда бөтен җирдә таралган. Сабагының биеклеге нинди культураны чүпләвенә бәйле. Яфраклары сызыклы, кырыйлары керфекле. Чәчәк төркеме — таралучан берьяклы себеркәч. Һәрбер ботак очында ике-өч төкле бөртекчәсе булган башак, яралгыны тыгыз томалап тора торган тышча б-н капланган. Бөртеге куе көрән төстәге буынтыксыман бөтерелгән кылчыклы, өлгерү барышында башакларында 2–3 кылчык күренә, алар ярдәмендә солычык солыдан аерыла. С. бөртекчәсенең төбендә төкле дагасы бар (солыда юк). Тамыр системасы туфракка 1,5 *м* га кадәр тирәнлеккә китә. С. тишелеп чыкканнан соң 65–75 көндә өлгерә. Тишемнәре, гадәттә, каен бөреләре ачылганда күренә башлый. Орлыктан үрчиләр. Бер үсемлек 600 гә кадәр орлык бирә, алар яз көне 25 *см* тирәнлектән үсеп чыга. С. туфракны бик нык киптерә, аның уңдырышлылыгын киметә, культуралы үсемлекләр (бодай, арпа, солы, борчак h.б.) чәчүлекләрен басып китә, аларның уңышын киметә. Солы б-н җиңел серкәләнә, аның сорт сыйфатларын начарайта. Хайваннарга С. б-н чүпләнгән ашлыкны пешекләп (парлап) яисә тарттырып бирәләр.



Татарстанда 379 мең *га* сөрүлек җир, ш.и. 50 мең *га* ы бик каты чүпләнгән; аеруча Алексеев, Зәй, Аксубай, Актаныш, Сарман, Чистай, Буа һәм Яңа Чишмә р-ннарында киң таралган. Көрәш чаралары: орлыклык материалны чистарту, туфракны чиста пар астында тоту, соңгы язгы культуралар (тары, карабодай) чәчү, анда С.ны чәчү алдыннан катламлап эшкәртү б-н бетерәләр; гербицидлар (карбин, триаллан, далапан h.б.) куллану.

*Әд.:* Колмаков П.П. Овсюг. М., 1975; Памятка по борьбе с овсюгом в Татарской АССР. К., 1978.

**СОЛЫЯ́З** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 15 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Бөгелмә-Азнакай автомобиль юлы буенда. 2010 елда 55 кеше (руслар) яши. 19 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Дмитровский, Соловъяз исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе, ятим балалар йорты эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 595 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Сумароково волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 270, 1889 да — 200, 1897 дә — 260, 1910 да — 226, 1920 дә — 418, 1926 да — 341, 1938 дә — 480, 1949 да — 218, 1958 дә — 181, 1970 тә — 137, 1979 да — 97, 1989 да — 60, 2002 дә — 47 кеше.

**СОЛЬ-ИЛЕ́ЦК (Тозтүбә) РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* көньягында урнашкан. 1927 елның 30 маенда оештырыла. Мәйданы — 5,2 мең *км*$^2$. Үзәге — Соль-Илецк шәһәре (Оренбургтан 77 *км* көньяктарак). Халкы — 52128 кеше (2013). Татарлар саны: 1970 тә — 4818, 1979 да — 4871, 1989 да — 4876, 2002 дә — 5241, 2010 да — 4780 кеше. Татарлар, нигездә, Соль-Илецк шәһәрендә (2740 кеше), Линёвка (736) һәм Яңа Илецк (468) авылларында яшиләр. Рев-циягә кадәр Соль-Илецкида 3 мәчет (1932 дә — 2 се, 1962 дә 1 се ябыла) эшли. Хәзерге вакытта — 1 мәчет. Совет чорында татар мәктәбе, китапханә, клуб (аның каршында татар драма театры эшли) була. 1998 дән Линёвкада «Мирас» ансамбле (2003 тә халык ансамбле исемен ала), 2003 тән «Яшь нур» балалар фольклор төркеме эшли; җирле китапханә татар вакытлы матбугатын алдыра. 2007 дә Яңа

Илецкида «Миләшләр» үзешчән ансамбле оештырыла. Соль-Илецк б-н шагыйрь М.*Җәлилнең* тормышы бәйле.

**СО́МОВ** Николай Никитович (22.5.1901, хәзер Рязань өлкәсенең Михайловский р-ны Лобановские Выселки а. — 25.10.1985, Казан), химик-технолог, сәнәгый җитештерүне оештыручы, полковник-инженер, техник фән. канд. (1967). Мәскәү химия машиналары төзү ин-тын тәмамлый (1935). 1911–19 елларда Петроградның төрле пр-тиеләрендә оста ярдәмчесе булып эшли. 1923–29 да Черкизов «Мосхимоснова» химия з-дында: слесарь, механик, директор урынбасары, директор. 1929–34 тә П.Л.Войков исем. химия з-дында (Мәскәү) баш механик урынбасары. 1934–35 тә С.М.Киров исем. СК-2 з-дында (Воронеж ш.) баш механик урынбасары. 1935–39 да Фотокинохимтрестта (Мәскәү) химия машиналарын проектлаучы инженер. 1939–40 та Казандагы В.В.Куйбышев исем. 8 нче кино тасмалары ф-касы (1958 дән В.В.Куйбышев исем. Казан химия з-ды) директоры урынбасары, капиталь төзелеш идарәсе башлыгы, 1940–50 дә һәм 1952–61 дә директоры; бер үк вакытта, 1956–61 дә, Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү кинофотоин-тының Казан ф-лы директоры. 1950–52 дә СССР Кинематография министрлыгының Баш кино тасмалары идарәсе башлыгы. 1961–74 тә химия-фотография сәнәгатенең Казан фәнни-тикшеренү технол. һәм проектлау ин-ты директоры. СССРда химия-фотография производствосын оештыручыларның берсе. С. җитәкчелегендә фабрика химия-фотография сәнәгатенең иң эре пр-тиесенә әверелә, яңа производстволар төзелә һәм үзләштерелә, төп технол. җиһазлары реконструкцияләнә, продукция ассортименты 100 ләп исемне колачлый, илдә беренче тапкыр кинонегатив тасма, астрономик күзәтүләр өчен гидротиплы һәм төсле плёнкалар, рулонлы рентген плёнкасы, рентген җайланмалары өчен зур кадрлы плёнка, металл ябыштыручы плёнкалар һ.б. эшләнә; 10 нан артык торак йорт, тулай торак, балалар бакчалары, стадион һ.б. төзелә. Уйлап табуга 9 патенты бар. С. эшләнмәләре тармакның фототехника һәм фотокәгазь пр-тиеләрендә җитештерүгә кертелә. Гражданнар сугышында катнаша. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Д я т л о в а А.М. «ТАСМА». Годы, люди, судьбы...: В воспоминаниях и документах (от УЭС до АО «Тасма-Холдинг»). К., 1996; ш у л у к. Тасмовцы второй мировой...: Документы, воспоминания, мемуары. К., 2001; Х а б и б у л л и н А.С. Испытание временем. К., 2008.

*А.М.Дятлова.*

**СОН** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Бөрсет елгасының (Кама елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 22,8 *км*, бассейнының мәйданы 129 *км²*. Мамадыш р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Югары Сон авылыннан 7 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Түбән Сон авылыннан 1 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 195 *м*, тамагыныкы — 77 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. С.нең 0,6 дан 3,9 *км* га кадәр озынлыктагы 10 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км²*. Туенуы катнаш, яртысыннан артыгы кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 158 *мм*, ташу агымы катламы 93 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,029 *м³/с*. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. С. бассейнында суының гомуми күләме 0,1 млн. *м³* булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**СОНЕ́Т** (итал. sonetto — җыр), катлаулы строфаларның бер төре, шигъри форма. Ул 14 шигъри юлдан тора: 1 кисәге — 2 дүрт юллы шигырьдән (катрен), 2 кисәге 2 өч юллы шигырьдән (терцет) гыйбарәт, дүрт юллы строфалар а б б а яки а б а б рәвешендә рифмалаша. Өчәр юллы соңгы строфаларда: 1) беренче юл б-н икенче юл рифмалаша, һәм ул очракта беренче терцетның өченче юлы икенчесенең өченче юлы б-н а а б — в в б рәвешендә рифмалашып килә, яисә 2) беренче терцетның өченче юлы икенчесенең икенче юлы б-н рифмалаша, һәм бу юлы аның беренче һәм өченче юллары в в г — д г д рифмасы б-н бәйләнәләр. Татар әдәбиятында С. 1930 елларда барлыкка килә. Беренче тәҗрибәләр Ш.Маннур («Сонетлар циклы», 1939) иҗатында күзәтелә башлый. Сугыштан соңгы елларда С.ны М.Хөсәен, Ш.Мөдәррис яза. Соңыннан бу жанрга Р.Харис, Роберт Әхмәтҗанов, Р.Зәйдулла, Ә.Гадел мөрәҗәгать итә.

*Әд.:* Г а л и у л л и н Т. Шигърият баскычлары. К., 2002; Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. К., 2007.

*Н.М.Йосыпова.*

**СОПА́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Сумка елгасының (Идел елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 10,3 *км*, бассейнының мәйданы 29 *км²*. Яшел Үзән р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Соловьёвка авылы янында, тамагы Бело-Безводный авылыннан көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 165 *м*, тамагыныкы — 64 *м*. С.ның фәкать Кече Ключи авылына кадәр булган югары агымы гына даими, биредә ул җир асты сулары б-н туена; урта һәм түбән агымнары җәен кибә, һәм суы бары тик елганың тирән урыннарында гына кала. С.ның үзәне уртача текәлектәге кәсле кабарынкы-батынкы сөзәклекләрдән торучы киң сызадан гыйбарәт. Су җыелу мәйданының шактый өлеше сукаланган, аның урманлылыгы 30%. С.ның 0,6 *км* озынлыктагы уң кушылдыгы бар. Елга юлы бормалы. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км²*. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км²*. Гидрологик режимы көчле ташу (якынча бер ай дәвам итә) һәм югары су муллыгы б-н характерлана, бу вакытта суның чыгымы 10–15 *м³/с* ка, ә уртача болганчыклыгы 10–11 *г/л* га кадәр арта. Елга бассейнында урман үсемлекләренең аз булуы сәбәпле, туфрак эрозиясе көчле үсеш алган, җәйге көчле яңгырлардан һәм язгы ташулар вакытында С.дан Сумка елгасына күп кенә комсыл-балчыксыл матдәләр агып керә, алар исә Раифа күленең төньяк өлешенә күчә. Елга, гадәттә, ноябрь башында туңа. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

*Әд.:* Т а й с и н А.С. Озёра Приказанского района, их современные природные антропогенные изменения. К., 2006.

**СО́ПИН** Владимир Фёдорович (24.9.1946, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (1988), Россия Ракета һәм артиллерия фән. академиясе мөхбир әгъзасы (2003), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1996). 1969 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1976–94 тә Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында бүлек башлыгы, директор урынбасары, проф. (1992), 2001–08 дә директоры; 1994–2001 дә Казан технол. ун-тының проректоры, 1996 дан аналитик химия, сертификация һәм сыйфат менеджменты каф. мөдире. Хезмәтләре полимер композицион материалларны тикшерүгә, рецептурасына һәм җитештерү технологиясенә карый. С. җитәкчелегендә эшләнгән физик-химик методикалар ярдәмендә синтез процессында целлюлоза нитратлары формалашу закончалыклары тикшерелә, төрле маркалы целлюлозалар реакцияләре кинетикасы, молекуляр-масса һәм композицион составлары өйрәнелә. Дарыларга микъдар һәм сыйфат ягыннан анализ ясала, аларның химик ныклыгы, физик-механик характеристикалары, дары һәм янучан материал компонентларының үзара туры килүчәнлеге билгеләнә, дарыларны саклауның гарантия вакытын ике тапкыр арттыруга нигезләмә бирелә. Нитроцеллюлоза чыгару өчен яңа типтагы целлюлоза чималы (агач целлюлозасы нигезендә) булдырыла. Порошоксыман полимер материаллар технологиясе; целлюлоза эфирларын алу өчен каты фазалы реакция технологияләре; дарының югары энергияле маркалары (ш.и. саклау вакыты чыгып үтилләштерелгән дарылардан) рецептуралары һәм принципиаль технологияләре; скважиналарның нефть бирүчәнлеген арттыру өчен составлар һәм җайланмалар эшләнә. Уйлап табуга 45 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СЭВның Оборона мәсьәләләре буенча даими комиссиясе эшче төркеме җитәкчесе (1985–90). СССР МС бүләге (1986), ТР Дәүләт бүләге (1997), РФ хөкүмәте бүләкләре (2002, 2008) лауреаты. Медальләр, ш.и. ЮНЕСКОның алтын медале һәм «21 йөз лидеры» дипломы б-н бүләкләнә (2001). Россиянең мактаулы гражданы (2008).

Х е з м.: Структурно-кинетические особенности получения и термодиструкции нитратов целлюлозы. М., 2005 (автордаш); Оборудование производства сферических порохов. К., 2007 (автордаш); Коллоидные свойства и каталитическая активность систем на основе алкилфенолов и их производных. К., 2009 (автордаш).

*Әд.:* Оружие и технологии России. Т. 12. Боеприпасы и средства поражения: Энцикл. М., 1999; Рос-

сийская академия ракетных и артиллерийских наук. М., 2008.

**СОРАВЫ́Л** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 34 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ырым елгасы буенда. 2010 елда 221 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1710 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында — Янгозина, 1940 елларга кадәр Янгозино-Суринская исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.да укырга-язарга өйрәтү мәктәбе, 2 тегермән, 2 тимерчелек, ярма яргыч, вак-төяклəр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1225,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Цивильск өязе Иске Тәберде волостенда, 1920 дән Чуаш автономияле өлкәсе составында, 1921 дән ТАССРның — Буа, 1921–22 лəрдән Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 17 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 128 ир-ат; 1859 да — 379, 1897 дә — 740, 1908 дә — 885, 1920 дә — 881, 1926 да — 903, 1938 дә — 809, 1949 да — 803, 1958 дә — 623, 1970 тә — 494, 1979 да — 410, 1989 да — 271, 2002 дә — 208 кеше.

**СО́РГО** (Sorghum), кыяклылар семьялыгыннан берьеллык яисә күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы; бөртекле һәм терлек азыгы культурасы. С. чыгышы б-н күп санда кыргый төре үскән Көнчыгыш Африкадан (Эфиопия һәм Судан). Культурада таралганнары: гади С. (S. vulgare), «Джугара» (S. sernuum), «Дурра» (S. durra), «Гаолян» (S. japonicum), «С. кафрское» (S. caffrorum), «С. хвостатое» (S. caudatum), «Дохна» (S. dochna) — бөртекле С.; «С. сахарное» (S. saccaharatum), «С. веничное», яисә «Себеркәчле С.» (S. technicum), судан үләне (S. sudanense) — терлек азыгы соргосы. С. ыругына ш.у. «Гумай» (S. halepense) — чүп үләне һәм терлек азыгы, гади С.ның «Гумай» һәм судан үләне б-н гибридлары керә. Культура үсемлеге буларак б.э.к. 4–3 меңьеллыктан үстерелә. Җылы яратучан, корылыкка чыдам культура, туфрак шартларына җиңел яраклашуы б-н аерылып тора. Тышкы яктан кукурузга охшаган. Тамыр системасы көчле, 2–2,5 *м* тирәнлеккә китә. Сабагы туры, 0,5 тән 7 *м* га кадәр биеклектә, өлгергәч коры (бөртеклеләрнең күп сортлары һәм «С. веничное») яисә сусыл (С. сахарное) була. Бөртекле С. үсемлеге берничә сабаклы. Яфрагы ланцетсыман, читләре очлы. Чәчәк оешмасы — туры, җәенке, 10–70 *см* озынлыктагы иелгән яисә бөгелгән себеркәчле. Җимеше — түгәрәк формадагы бөртекчә, буразнасыз, ялангач яисә элпәле, ак, сары, соры, көрән, кара төстә; 1000 данә орлыкның авырлыгы 5–32 *г*. Бөртегеннән (составында 61–68% крахмал, 7,8–16,7% аксым, 1,7–6,5% май бар) он, ярма, спирт, крахмал һ.б. әзерләнә, саламыннан үрелгән әйберләр, кәгазь, себерке ясала. «С. сахарное» сорты сабакларыннан патока алына. Бөртеге һәм яшел массасы терлек азыгы буларак файдаланыла. Күп төрләренең яшь үсемлекләре агулы. С.ны бөртекле ашлык буларак — тулысынча өлгергәч, силос өчен — балавызлангач, яшел азык өчен себеркәчләрен ата башлаган вакытта җыялар. ТРда зур булмаган мәйданнарда «Кинельское 3», «Волжское 51» сортлары үстерелә. Корткычлары — гөбләләр, чыбык личинка, ябалакчыклар һәм сабак күбәләкләре. Авырулары — каты һәм тузанлы кисәү гөмбәсе, сабак һәм тамыр череге, бактериоз һ.б.

*Әд.:* Бадина Г.В., Королёв А.В., Королёва Р.О. Основы агрономии. Л., 1988.

**СОРНА́Й**, татар халкының телле тынлы музыка уен коралы. 18 йөздә галим-этнографларның хезмәтләрендә искә алына. В.В.Радловның төрки телләр сүзлегенә караганда, С. термины төркичә «сур» (мөгез) һәм «най» (камыш) сүзләреннән, ягъни камыш сыбызгыдан ясала. Әлеге термин б-н бу уен коралын гына түгел, ярым ай рәвешендәге 18 кыллы яссы арфаны да атыйлар (Г.Ф.Миллер юльязмалары). Татар халкының төрле жанр әсәрләрендә искә алынуы С.ның борынгылыгын күрсәтә. Мәс., «Сәрвиназ» әкият-табышмагында Таймас хан сараендагы тантананы сурәтләгәндә, берничә музыка уен коралында, ш.и. С.да уйнау турында әйтелә. 120–200 *мм* озынлыкта, эчке диаметры 4,5 *мм*; теленең буе — 20–30 *мм*, киңлеге — 4,5 *мм*; бармак өчен 6 тишектән гыйбарәт булган камыш сабактан эшләнә. С.ның тавышы көчле; оста эшләнгән уен коралы тембры буенча кларнетка якын. Биш тишекле уен коралының диапазоны — секста, авазлар рәте ангемитон, алты тишекленең — октава, авазлар рәте диатоник. С.ның башкару мөмкинлекләре оста музыкант тарафыннан төрле техник ысуллар кулланылганда күренә. Башкаручы репертуарында С. өчен махсус бию һәм җыр көйләре, озын һәм кыска көйләр була. Алар төрле ритмик алымнар, штрихлар, мелизмнар б-н баетыла; «Сорнайда көйләү» кебек чиста инструменталь музыка импровизация рәвешендә башкарыла.

*Р.Ф.Халитов.*

**СОРНА́Р АУЧЫЛЫ́К ТЫЮЛЫГЫ́**, комплексы. Арча һәм Балтач р-ннары терр-ясендә урнашкан. 1965 елда оештырыла. Мәйданы 14,4 мең *га*, ш.и. урманнар — 10,8 мең *га*, су-сазлык — 7 *га*. Поши, кабан дуңгызы, төлке, янутсыман эт, бурсык, сусар, сәләүсен, сасы көзән, Америка чәшкесе, тиен, ак куян, көртлек, боҗыр; ТРның Кызыл китабына кергән төрләрдән ак ябалак яши.

*Р.Э.Чиспияков.*

**СОРО́КИН** Анатолий Степанович (13.7.1934, Югары Ослан р-ны Веденская Слобода а.), төзүче-инженер, «Татнефтегазстрой» төзү-монтаж җитештерү берләшмәсе башлыгы (1984–96), ТАССР, РФнең атказ. төзүчесе (1981, 1991). Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый (1958). 1958–97 елларда «Татнефтегазстрой» төзү-монтаж җитештерү берләшмәсендә эшли: 29 нчы трестта мастер, прораб, бүлек башлыгы, төзү-монтаж идарәсе баш инженеры, 5 нче трестның баш инженеры, управляющие, берләшмәнең баш инженеры (1981 дән). С. җитәкчелегендә төркемле насос станцияләренең промысел объектлары, товар парклары, төркемле нефть җыю һәм транспортлау җайланмалары, җир асты һәм промысел эчендәге үткәргеч торбалар, тораклар, социаль-мәдәни объектлар һ.б. файдалануга тапшырыла. 1985–90, 1990–92, 1992–95 тә ТАССР, ТССР, ТР ЮСлары депутаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТАССР ЮС Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**СОРО́КИН** Василий Иванович (17.12.1848, Екатеринбург ш. — 1919, шунда ук), агрохимик, химия д-ры (1887), проф. (1893), Казан ун-тының атказ. профессоры (1899). 1870 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (1906 га кадәр). 1871–74 тә аграр химия һәм агрономияне өйрәнү максаты б-н Петровский игенчелек һәм урманчылык академиясендә (Мәскәү) фәнни командировкада була. 1874–79 да химия лаб-ясе каршындагы музей саклаучысы, аграр кабинет оештыручы һәм аның мөдире (1880 нән, Казан). Хезмәтләре органик химиягә карый. С кабатланучан икеле бәйләнешле чиксез кушылмаларның төзелешен, диаллил һәм диаллилэтилкарбинолның оксидлашу реакциясен; матдәләрнең оптик активлыгы б-н составы арасындагы бәйлелекне (глюкоза анилидлары һәм толуидлары мисалында) тикшерә. Үсемлекләрнең азотны, азотлы-ачы һәм аммиак кушылмаларын үзләштерү сәләтен өйрәнә. 1900 еллар башында студентларга а.х. анализы, ашламалар буенча лекцияләр укый; губерна земстволарына һ.б. оешмаларга а.х. мәсьәләләренә караган күрсәтмә-киңәшләр бирә; Казан ун-ты каршындагы Табигыятьчеләр җәмгыяте эшендә катнаша (халык алдында лекцияләр укый).

*Әд.:* Быков Г.В. Казанская школа химиков-органиков // Исследования по истории органической химии. М., 1980; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

**СОРО́КИН** Григорий Фёдорович (19.1.1918, Казан өязенең Царицыно а. — 11.10.1983, Казан), радиоинженер, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1967). Казан авиация ин-тын (1943), авиация сәнәгате академиясен (Мәскәү, 1953) тәмамлый. 1943–78 дә Казан «Радиоприбор» ҖБдә: цех башлыгы, өлкән инженер-технолог, баш күзәтче (контролёр), заводның баш технологы (1953 тән), баш инженер (1960 тан). Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге махсус техника өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. Хезмәт Кызыл байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**СОРО́КИН** Игорь Иванович (3.5.1927, Зөя р-ны Түбән Ослан а. — 21.8.2006, Казан), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1956). 1941–91 елларда «Казан оптика-механика заводы» ҖБдә: токарь, мастер, цех башлыгы урынбасары, төркем җитәкчесе, СКБ з-дында бүлек башлыгы; «Фотон» үзәк конструкторлык бюросында: инженер-конструктор, конструкторлык бүлеге башлыгы,

әйдәп баручы конструктор (1976 дан). Уйлап табуга 9 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге идарә итү системаларын булдырганы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**СОРО́КИН** Николай Васильевич (29.11.1846, Курск губ., Корочанск өязе Лазоревка а. — 23.3.1909, Казан), ботаник, миколог, ботаника докторы (1874). Харьков ун-тын тәмамлый (1869), шунда ук эшли. 1871 елдан Казан ун-тында, атказ. ординар проф. (1896), ботаника каф. профессоры (1897 дән). Казан ун-ты каршында хатын-кызларның югары курсларын ачуны (1876) башлап йөрүче. Хезмәтләре түбән төзелешле гөмбәләрнең үсеше тарихын, систематикасын, төзелешен һәм үрчүен өйрәнүгә карый. Микологик гербарий төзүче (Ленинград өлкәсенең Пушкин ш.). Күп кенә гөмбә төрләренә С. исеме бирелгән. Көньяк Уссури краена оештырылган экспедиция вакытында фәндә элек билгеле булмаган, соңыннан аның хөрмәтенә Bipolaris sorokiana дип аталган фитопатоген гөмбә төрен (кыяклыларның киң таралган паразиты) таба. Барлык таксономик гөмбә төркемнәреннән 50 дән артык яңа төрне тасвирлый һәм исемләгән бирә. «Ботаникадан кыскача курс. Үсемлекләр морфологиясе һәм систематикасы» («Краткий курс ботаники. Морфология и систематика растений», 1886) дәреслеге авторы. 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары, ш.у. имп. Александр III истәлегенә бриллиант йөзек һәм Александр тасмасында Имп. көмеш медале б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Микологические очерки. Хар., 1871; Растительные паразиты человека и животных как причины заразных болезней: В 4 вып. СПб., 1882–86.

*Әд.:* Д ё м и н а Г.В. Николай Васильевич Сорокин. К., 2006.

**СОРО́КИН** Николай Михайлович (8.7.1941, Тәтеш р-ны Олы Шәмәк а.), журналист, язучы, ТАССРның һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1988, 2002). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1966), «Советская Татария» г-тасында эшли (әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире), 1977 елдан ИТАР-ТАССның Татарстан буенча үзхәбәрчесе. Шул ук вакытта чуашча «*Сувар*» г-тасын һәм «*Шурампус*» ж-лын оештыручы һәм баш мөхәррире (1993–98). С.ның язма, очерк һәм мәкаләләре «Правда», «Известия», «Советская Россия» г-таларында басыла. «Түбән Камадан репортаж» («Нижнекамский репортаж», 1978), «Эшче династияләр» («Рабочие династии», 1986), «Шишкин нарат урманнарындагы таң» («Над шишкинским бором рассвет», 1989) очерклар җыентыклары, «Тормыш тәгәрмәче» («Колесо жизни», 1990) китабы, «КамАЗ сәүдәгәре» («Купец с КамАЗа», 2004) һ.б. повестьлар авторы. «Мәңгелек Идел» («Вечная Волга», 1–3 кит., Чабаксар, 2006–08) романында 20 йөздә Татарстан крәстияннәренең фаҗигале тарихы сурәтләнә.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3; Кто есть кто в Республике Татарстан. К., 2005.

**СОРО́КИНА** Валентина Васильевна (27.2.1936, Аксубай р-ны Михайловка а.), дуңгыз караучы, Соц. Хезмәт Герое (1976). 1956–85 елларда «Восход» с-зында, 1985–91 дә дуңгызлар симертү буенча хуҗалыкара берләшмәдә (Аксубай р-нында) эшли. 1 меңләп баш дуңгыз карап, 600 *г* уртача тәүлеклек артым ала. Герой исеме бишьеллык планны (1971–75) һәм соц. йөкләмәләрне үтәгәндә ирешкән уңышлары өчен бирелә. 1971–74 тә РСФСР ЮС депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә. Аксубай төбәк музеенда С.га багышланган стенд куелган.



В.В. Сорокина.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**СОРО́ЧИНСК РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* көнбатыш өлешендә урнашкан. 1928 елда оештырыла. Мәйданы — 2,8 мең *км*². Үзәге — Сорочинск шәһәре (Оренбургтан 170 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 13354 кеше (2013). 2010 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 612 кеше. Аларның күбесе Сорочинск шәһәрендә (1890 кеше) яши, бу шәһәр район составына керми. Татарлар Яңа Белогор (Яңавыл) (2002 дә 500 ләп) һәм Аюлы авылларында яшиләр. Яңа Белогорга 1767 дә Казан губернасыннан күченүчеләр нигез сала. 1920 ләргә кадәр Сорочинскида (1915 тән) һәм Яңа Белогорда (19 йөз ахырыннан) мәчетләр эшли. 1919 да Яңа Белогорда татар мәктәбе ачыла, 1961 дән татар теле фән буларак укытыла. Хәзерге вакытта авыл мәдәният ансамбле, мәктәп каршында «Чишмә» фольклор ансамбле эшли. Сорочинскиның 3 нче мәктәбендә татар теле факультатив дәресләрдә өйрәнелә. Сорочинскида (2002 дән) һәм Яңа Белогорда мәчетләр бар. 2001 дән Сорочинскида төрки халыкларның милли мәдәниятен үстерү максатында «Туган тел» төбәк иҗтимагый хәрәкәте эшли. Яңа Белогорда тарихчы Г.*Батталл* туган.

*Әд.:* И с к а н д а р о в Р.Ш. Оренбургские татары: Историко-энцикл. очерк. К., 2009.

*С.Г.Батталова.*

**СОРЫ́ КӨРТЛЕ́К** (Perdix perdix), фазан кошлар семьялыгындагы кош. Евразиянең урман, урман-дала һәм дала зоналарында таралган. Татарстанның барлык терр-ясендә очрый, әмма саны күп түгел һәм ел саен үзгәреп тора. 30–50 заттан торган көртлек көтүе көзен һәм кышын очрый. Кырларда, болыннарда, урман буйларында яши. Гәүдәсенең озынлыгы 26 *см*, авырлыгы 400–500 *г*. Башындагы каурый капламы коңгырт, аркасы соргылт, аркылы җирән-кызыл буйлы, корсагы коңгырт таплы ак; түшеннән һәм корсагының ике ягы буйлап киң аксыл-соры сызык үтә. Утрак кош. Оясын җирдә, үлән арасында яки куаклыкта кора. Оялау чорында парлашып, башка вакытта көтү булып яшиләр. Апрель ахыры – май башында соргылт яки зәйтүнсыман-сары 10–20 йомырка сала. Балалары июньдә чыга. С.к. үлән орлыклары, җиләкләр, җир өсте моллюсклары б-н туклана. 1986 елга кадәр спорт сунарчылыгы объекты. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**СОРЫ́ КҮСЕ́**, п а с ю к (Rattus norvegicus), күселәр ыругыннан имезүче җәнлек. Туган җире — Көньяк-Көнчыгыш Азия. Татарстан терр-ясендә киң таралган төр. Торак һәм хуҗалык каралтыларында (подвал, терлек торакларында, сарай, амбарларда) яши. Җәен еш кына бакчаларга, ташландык урыннарга, кырларга күчә һәм анда вакытлы өннәр ясый. Гәүдәсенең озынлыгы 25 *см* га, авырлыгы 500 *г* га җитә. Койрыгы гәүдәсенә караганда кыскарак (гәүдәсенең уртача 75% ы кадәр). Гәүдәсе тыгыз, танавы җәенке һәм киң. Колак яфрагы зур түгел. Аркасы ачык җирәннән кара-сары-коңгырт төскә күчә. Корсагы аксыл, йонының төбе кара. Күбесенчә эңгер-меңгердә һәм төнлә актив. Гадәттә, төркем булып яшиләр. Уңай шартлар булганда, ел әйләнәсе үрчиләр. Буазлык чоры 20–23 көн дәвам итә. Уртача 7–8 бала китерә. Җенси яктан 3,5–4 айда җитлегә. Кырчылык, терлекчелек тармакларына, ашлык амбарларына зур зыян китерә. Күп кенә йогышлы авыруларны (ш.и. түләмә, бруцеллёз, ашказаны-эчәк инфекцияләре) таратучы.

**СОРЫ́ УРМА́Н ТУФРАКЛАРЫ́**, туфрак тибы, яфраклы һәм ылыслы урманнарда континенталь климат шартларында периодик юылулы су режимы шартларында күбесенчә карбонатлы токымнарда формалаша. Туфрак барлыкка килү үзенчәлекләре: зур күләмдә коелган үсемлек калдыклары, органик калдыкларның югары көллелеге һәм аларның нигезләргә бай булуы. С.у.т.ның барлыкка килүе төп ике капма-каршы процесс — ана токымнарның дымлану үзенчәлекләре кальций һәм магний б-н азрак туенуы аркасында җиңелчә формада — көлсу туфраклар һәм үсемлекләрнең туклану элементлары, гумус туплану б-н беррәттән туфракның өске катламында суга чыдам структура хасил итә торган кәсле туфраклар күпләп оешу йогынтысында бара. Урманнарда С.у.т. профиле 150 *см* га, сөрүле җирләрдә 200 *см* га кадәр; түбәндәге горизонтлардан тора: $A_0$ — урман түшәлмәсе; $A_1$ — гумуслы горизонт, төсе аксыл-сорыдан карасу-сорыга кадәр, вак төерсыман структуралы; $A_1A_2$ — гумуслы-элювиаль горизонт, чикләвексыман структуралы, структур берәмлекләрнең кырларында кремнезёмның аксыл сибелмәләре күренә; $A_2B$ — көлсуланган күчеш горизонты, карарак төстә, плитә-чикләвексыман яки чикләвексыман структуралы; B — иллювиаль горизонт, карасу-көрән яки карасу-коңгырт төстә, эре чикләвексыман структуралы, аска таба — призматик, ялтыравык кабыклы һәм саркып чыккан утырмалы, горизонтның өске өлешендә шактый гына кремнезём сибелмәсе: C — карбонатлы ана токым. Гумуслы горизонтның калынлыгы һәм аның төсе, гумус күләме, көлләнү дәрәҗәсенә бәйле рәвештә

С.у.т. аксыл-соры (20 *см* га кадәр $A_1$, гумус 3% тан аз), соры (25 *см* га кадәр, 3–5%) һәм карасу-соры (35 *см* га кадәр, 5% тан күбрәк) астипларга бүленә.

Татарстанда С.у.т. 2511,3 мең *га* (гомуми мәйданның 37% ы) мәйдан били. Идел алдында, Идел алдының төньягында, Кама аръягының көньяк-көнбатыш, үзәк һәм төньяк-көнчыгыш төбәкләрендә таралганнар. Туфракларның 43% тан артыгы — аксыл-соры, 33% — соры, 24% — карасу-соры. Алар өчен ана токымнар булып лёссыман комсыл балчык, делювиаль комсыл балчык һәм балчыклар, Пермь чоры токымнарының элювиаль утырмалары тора. Соңгы очракта гумуслы горизонт коңгырт төсмер (мондый туфраклар элек мөстәкыйль коңгырт-соры урман туфраклары тибы буларак билгеләнгән) ала. С.у.т. дренажлы яссы субүләрдә һәм аларның сөзәк яки җиңелчә авыш тау битләрендә урнашкан, гадәттә, аларның югары өлешендә — аксыл-соры, түбәндә — карасу-соры туфраклар. С.у.т.на гумусның, үсемлекләрнең туену элементларының шактый күп, җиңелчә әче реакцияле булуы, уңай җылылык һәм су режимнары, югары биологик активлык хас. С.у.т.ның 64% тан артыгы сөрүлек җир буларак файдаланыла. Уҗым һәм сабан культуралары, азык-төлек, техник яшелчә, җиләк-җимеш культуралары игелә. Туфракларның 23% ка якын мәйданын урманнар, ш.и. югары продукцияле имәнлекләр били. С.у.т.ның уңдырышлылыгын күтәрү өчен органик һәм минераль ашламалар кулланалар, известьләү үткәрәләр.

*Әд.:* Серые лесные почвы Татарии, их плодородие и рациональное использование. К., 1991.

*Ф.Г.Борһанов.*

**СОРЫ́ ЧЕБЕННӘ́Р** (Chrysops), кигәвеннәр ыругы. Уртача зурлыктагы (7–12 *мм*) канәчкеч чебеннәр. Канатының алгы чите коңгырт, өслеге коңгырт аркылы тасмалы. Парлы фасетлы күзләре башының шактый өлешен билиләр, металлсыман яшькелт төстә. С.ч. үсеше — тулы әверешле. ТРда С.ч.нең 9 төре һәм 2 астөре яши. Аеруча болын С.ч.е (Ch. pictus) һәм гади С.ч. (Ch. relictus) киң таралган.

С.ч. кеше һәм хайваннар каны б-н туена. Чебенгә тулысынча тую өчен 100 *мг* га кадәр кан кирәк. Ләкин С.ч.нең авыз аппараты чәнчеп кисүгә җайлашкан булганлыктан сизелерлек авырту тудыра һәм саклагыч реакциягә очрый. Нәтиҗәдә, кигәвен туенырга өлгерми һәм бер хуҗадан икенчесенә күчә, бу исә хайваннар һәм кешеләр арасында патоген агентлар таралуга сәбәп була. С.ч.нең туләрәмә йоктыруда катнашуы исбатланган.

*Әд.:* Романов В.П., Боженко В.П., Яковлев М.Г. Материалы изучения пойменного туляремийного очага // Природная очаговость болезней человека и краевая эпидемиология. Л., 1955; Волкова М.И. К изучению слепней Tabanidae в Татарской АССР до затопления поймы Волги и после возникновения Куйбышевского водохранилища // Материалы итоговой научной конференции зоологов ВКК. К., 1970.

*В.А.Бойко.*

**СОРЫ́ ЯБАЛАКЛА́Р** (Strix), ябалак кошлар семьялыгыннан кошлар ыругы. 12 төре билгеле, Евразиядә, Төньяк Африкада һәм Төньяк Америкада таралганнар. Татарстанда 3 төре бар. Соры яки гади ябалак (S. aluco), озын койрыклы соры ябалак (S. uralensis) респ-каның барлык терр-ясендә очрый, әмма алар күп түгел. Утрак кошлар. Ылыслы һәм катнаш урманнарда яши. Сакаллы соры ябалак (S. nebulosa) — очып керүче бик сирәк төр. Кошларның якын-тирәгә күчеше вакытында, нигездә, көзен, кышын һәм иртә язда очрый. Гәүдәсенең озынлыгы 65 *см*, авырлыгы 600–1200 *г*, ана кошлар аталарыннан зуррак. Чуар, соры яки җирәнрәк төстә. Бит дискы яхшы үсеш алган. Колак тишекләре зур, тулысынча диярлек тире җыерчыгы б-н капланган. Күзләре зур, кара-коңгырт төстә. Томшыгы көчле, биек, ян-яктан кысылган. Каурый капламы йомшак, күпереп тора. Канатлары киң һәм түгәрәкләнгән. Аяклары тырнакларына кадәр каурыйлы. Тырнаклары очлы, бөгелгән. Соры ябалакның койрыгы чагыштырмача кыска, озын койрыклы соры ябалак һәм сакаллы соры ябалакның исә озын, аркылы сызыклары бар. Аерым парлар хасил итеп оялыйлар. Ояларын агач кышшларында яки карга, саескан һ.б. кошларның иске ояларында коралар. Аксыл-чуар 2–6 йомырка салалар. Тычкансыман кимерүчеләр, кошлар, зур бөҗәкләр б-н тукланалар. Барлык төрләре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Соры ябалак.

**СОСНО́ВКА** елгасы, к. *Артъелга.*

**СОСНО́ВКА** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Әдәм елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 116 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 73%, чуашлар — 26%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новопоселённая Сосновка исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Казан Богородица чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе (1883 тә ачыла), 5 тегермән, 4 вак-төяк кибете була; чәршәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1188 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәм волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан — Алексеев, 1977 нең 29 августыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1859 да — 447, 1897 дә — 946, 1908 дә — 882, 1920 дә — 1094, 1926 да — 831, 1938 дә — 653, 1949 да — 468, 1958 дә — 442, 1970 тә — 451, 1979 да — 335, 1989 да — 112, 2002 дә — 189 кеше.

**СОСНО́ВКА** посёлогы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 22 *км* төньяктарак, Саурыш елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 37 кеше (чуашлар) яши. 1929 да нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Чистай кантоны Яңа Әдәм волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 81, 1949 да — 98, 1958 дә — 59, 1970 тә — 84, 1979 да — 84, 1989 да — 46, 2002 дә — 47 кеше.

**СОСНО́ВКА** посёлогы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 22 *км* төньяктарак, Урман Зәе елгасы буенда. 2010 елда 121 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1926 да Яңа Никольский авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оешкан көненнән ТАССРның Чаллы кантоны Акташ волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 267, 1949 да — 222, 1958 дә — 185, 1970 тә — 203, 1979 да — 158, 1989 да — 98, 2002 дә — 84 кеше.

**СОСНО́ВКА** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 17 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кырлай елгасы буенда. 2010 елда 251 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Мәдәният йорты, китапханә. 1636 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Сухая Сайра исеме б-н дә билгеле. 1713 тә алпавыт М.И.Писемский С.ның бер өлешен *Седмиозёрный пустынена* бирә. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә, почта хезмәте б-н шөгыльләнә. 1885–97 елларда земство мәктәбе эшли. 20 йөз башында тимерчелек, су тегермәне, 3 бакалея кибете, 8 юлаучылар йорты була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 224 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Чыпчык волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1726 да — 51, 1782 дә — 78 ир-ат; 1859 да — 261, 1897 дә — 183, 1908 дә — 191, 1920 дә — 290, 1926 да — 387, 1938 дә — 421, 1949 да — 334, 1958 дә — 264, 1970 тә — 238, 1989 да — 184, 2002 дә — 220 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**СОСНО́ВКА** посёлогы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 28 *км* көньяктарак, Сулы елгасы (Димнең сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 38 кеше (татарлар, руслар) яши. Торак пункт буларак, 1960 ның 16 февралендә теркәлә. Оешкан көненнән Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1989 да — 73, 2002 дә — 50 кеше.

**СОСНО́ВКА** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 27 *км* көнбатыштарак,

Гөбенә елгасы буенда. 2010 елда 25 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Кичке исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 208 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ульянково волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 17 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1859 да — 156, 1897 дә — 290, 1908 дә — 354, 1920 дә — 296, 1926 да — 301, 1938 дә — 315, 1949 да — 190, 1958 дә — 108, 1970 тә — 127, 1979 да — 117, 1989 да — 62, 2002 дә — 60 кеше.

**СОСНО́ВКА** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 44 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тимерлек елгасы буенда. 2010 елда 63 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Клуб, китапханә. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Иске Әлмәт волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1926 да — 70, 1938 дә — 125, 1949 да — 98, 1958 дә — 126, 1970 тә — 151, 1979 да — 106, 1989 һәм 2002 дә — 77 шәр кеше.

**СОСНО́ВКА** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 20 *км* көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 171 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1930 ларда нигез салына. Оешкан көненнән Беренче Май р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1949 да — 304, 1958 дә — 314, 1970 тә — 374, 1979 да — 248, 1989 да — 163, 2002 дә — 194 кеше.

**СОСНОВОБО́РСК РАЙОНЫ́**, *Пенза өлкәсенең* көнчыгышында урнашкан. 1928 елның 16 июлендә (1940 ның 17 февраленә кадәр — Литвино р-ны) оештырыла. Мәйданы — 1,6 мең *км*². Үзәге — шәһәр тибындагы Сосновоборск посёлогы (Пензадан 120 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 16075 (2013), татарлар — 5397 (2010) кеше. Татарлар, тупланып, Индерка (1745 тә — 345 ир-ат; 1877 дә — 2379, 1886 да — 2625, 1897 дә — 3061, 1959 да — 3557, 1979 да — 3952, 1989 да — 4085, 2002 дә — 4263, 2008 дә — 4300, 2013 тә — 4276 кеше), Сәләмәс (1989 да — 377 кеше), Әлмәш (1989 да — 316 кеше) авылларында яшиләр. Индерка (икенче исеме — Усман) авылына 18 йөз башына кадәр Пенза һәм Саранск өязләреннән күченгән йомышлы татарлар нигез сала. Пётр I заманында алар дәүләт крәстияннәре катлавына кертелә һәм аларга лашманлык хезмәте йөкләтелә. 19 йөз ахырына кадәр халкының төп шөгыле — игенчелек, терлекчелек, сәүдә, агач әзерләү һәм Сура елгасында бүрәнә агызу. 1912 елгы мәгълүматларга караганда, Индеркада 666 хуҗалык, 7 мәчет, 4 татар мәктәбе, базар; Сәләмәстә 1 (1825 кә кадәр — 2) мәчет була. Хәзерге вакытта Индерка авылы урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты фән буларак өйрәнелә, «Авылым», «Переменка» г-талары нәшер ителә, ел саен Казанга экскурсияләр оештырыла. 1990 нан авыл мәдәният йорты каршында «Былбылым» татар фольклор коллективы (1998 дә халык коллективы исеме бирелә) эшли. 2 мәчет бар, Болгарга зиярәт кылу оештырыла. Соц. Хезмәт Герое Х.М.Мәҗитованың тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге С.р. б-н бәйле. Индерка авылының истәлекле урыннары — 2 архит-ра истәлеге: сәүдәгәр Баишевлар йорты (19 йөзнең 2 нче яртысы) һәм таш мәчет (19 йөз ахыры).

*Әд.:* История Пензенского края: В 2 ч. Пенза, 1996–2000; А к ж и г и т о в А.М. Пензенские татары: краткая история, селения, народное творчество. К., 2001; Пензенская энциклопедия. М., 2001.

**«СОСНОВОБО́РСКИЙ»**, Тукай р-нындагы совхоз. 1981 елда «Татарстан» с-зы җирлегендә (Князево а.) оештырыла. 2000 нән агрофирма, 2003 тән нәсел репродукторы, 2004 тән нәсел үрчетү з-ды, шул ук елдан «С.» ҖЧҖ. 1996–2003 тә «Чаллы ит комбинаты» АҖ карамагында була. 2005 тә «С.» җирлегендә «Камский Бекон» ҖЧҖ оештырыла. Үзәк утары — Сосновый Бор посёлогы. А.х. файдалану җирләренең мәйданы — 3872 *га*, ш.и. сөрүле җирләр 2630 *га* (2004). А.х. җитештерүендә эшләүчеләр саны — 562 кеше. Төп тармагы — дуңгызчылык. Предприятие составында нәсел үрчетү фермасы, дуңгыз үстерү һәм симертү өчен 8 участогы булган терлекчелек цехы, терлек сую цехы һ.б. 1985 тә — 44,9 мең баш, 1995 тә — 54,4 мең, 2004 тә — 61,9 мең баш дуңгыз исәпләнә. Уртача тәүлеклек артым 1995 тә — 294 *г*, 2004 тә — 408 *г*. 1990 да 6512 *т*, 2004 тә 6821 *т* ит җитештерелә. 2000 дә хуҗалык җирлегендә дуңгыз ите җитештерүдә Голландия технологиясен кертү буенча республика уку үзәге ачыла. Хуҗалык ТАССР ВДНХсы дипломы (1985), Россия агросәнәгате «Алтын көз» күргәзмәсенең көмеш (2003) һәм бронза (2004) медальләре б-н бүләкләнә. Хуҗалык үсешенә иң күп өлеш кертүчеләр — А.Х.Алиев (1980–86), Т.Н.Хөрмәтуллин (1986–96), Ф.З.Мәгъҗанов (1996–99), С.М.Таҗипов (1999–2005).

*Әд.:* В а г и з о в Д.Н. И прилетели к нам голландские поросята... // Бизнес-класс. 1996. № 3; В и л ь д а н о в Р. Агрофирма «Сосновоборская»: Буклет. К., 2000.

**СОСНО́ВЫЙ БОР** (Наратлык) посёлогы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 20 *км* көнчыгыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 1025 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 69%, руслар — 27%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1979 да нигез салына, торак пункт буларак 1984 тә теркәлә. Халык саны: 1989 да — 167, 2002 дә — 885 кеше.

**СОСНО́ВЫЙ КЛЮЧ** (Керәшен Наратлысы) авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 14 *км* көньяк-көнбатыштарак, Олы Бахта елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 1 кеше (татар) яши. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 ларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.К.та 2 тегермән, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 696 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Мөслим волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 62 ир-ат; 1859 да — 208, 1897 дә — 417, 1908 дә — 484, 1920 дә — 565, 1926 да — 487, 1938 дә — 397, 1949 да — 252, 1958 дә — 231, 1970 тә — 122, 1979 да — 58, 1989 да — 25, 2002 дә — 7 кеше.

**СОСНО́ВЫЙ ЮРА́Ш** (Атау) авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 37 *км* төньяк-көнбатыштарак, Юраш елгасы (Вятка бассейны) буенда. 2010 елда 51 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, такта яру б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында С.Ю.та мәчет, мәктәп, тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1051,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Чиркәс волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 372, 1887 дә — 581, 1905 тә — 710, 1920 дә — 785, 1926 да — 822, 1938 дә — 491, 1949 да — 229, 1958 дә — 180, 1970 тә — 132, 1979 да — 64, 1989 да — 37, 2002 дә — 39 кеше.

**СО́ТНЯ** (йөзлек), 1) борынгы рус гаскәрләрендәге, рев-циягә кадәрге Россиядә казак частьларындагы бүленеш; 2) 11–18 йөзләрдә катлауларга бүленгән рус корпоратив оешмалары (мәс., сәүдәгәрләр С.сы, посад С.сы); 3) 16–18 йөзләрдә Украинада хәрби һәм адм.-терр. бүленеш берәмлеге; 4) 16 йөзнең 2 нче яртысында – 17 йөздә Казан төбәгендә вак адм.-терр. бүленеш берәмлеге, өязнең бер өлеше билгеләмәсе. С.ларга бүлү рус булмаган җирле халыклар яшәгән төбәкләргә хас була. Йөзбашлары (сотниклар) ясак түләүче халыклар яисә йомышлы катлау вәкилләре арасыннан сайлап куела.

*Д.Г.Мостафина.*

**СО́ТОВО** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 62 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 210 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 54%, татарлар — 46%) яши. Урман хуҗалыгы. Китапханә. 1930 ларда такта яру посёлогы буларак нигез салына. Оешкан көненнән Кызыл Йолдыз р-нында. 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1970 тә — 434, 1979 да — 375, 1989 да — 277, 2002 дә — 241 кеше.

**СОТО́НИН** Константин Иванович (26.2.1893, Казан губ., Лаеш өязе Балык Бистәсе а. — 14.3.1944, Югары Ослан р-ны Гребени а., башка мәгълүматлар буенча, 1945, Горький өлкәсе Ветлуга ш.), философ, психолог. Казан ун-тын тәмамлый (1916). 1917 елдан Петроградта фәнни командировкада була; тикшеренү эшен 3 нче шәһәр гимназиясендә укыту б-н берьюлы алып бара. 1919–22 дә Казан ун-тында, экспериментал психол., эстетика һәм филос. укытучысы. 1922 дән Казан хезмәтне фәнни оештыру ин-тының психотехник лабораториясен җитәкли, бер үк вакытта Шәрекъ пед. ин-ты профессоры. 1929 да «яшерен сәяси-фәлсәфи түгәрәк» оештыручы буларак кулга алына, 1930–33 тә Уралда сөргендә була. Аннан кайткач, Югары Ослан р-ның Гребени авылындагы химия пр-тиесендә эшли. Яңадан кулга алына, азат ителгәннән соң, Воткинск, Ветлуга шәһәрләрендә эшли. Хезмәтләре грек һәм немец философиясенә, психологиягә карый.

Х е з м.: Словарь терминов Канта. К., 1913; К вопросу об идеях Платона. П., 1915; Идея философской клиники: Введение в систему философии. К., 1922.

*Әд.:* М а л ы ш е в а С.Ю. Философия счастья Константина Сотонина // Татарстан. 1994. № 4; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.


**«СОТРУ́ДНИК БРА́ТСТВА СВЯТИ́ТЕЛЯ ГУ́РИЯ»** («Изге Гурий борадәрлеге хадиме»), атналык дини журнал. *Изге Гурий борадәрлеге* хадимәләре түгәрәге басмасы. 1909 елдан алып 1911 нең декабренә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, 1911 нең 7 августыннан «Сотрудник Приволжской миссии» исемендә чыга. Саннарын исәпкә алу катлаулы: 1909 ның 5 ноябренә кадәр 9 саны басыла (1–9); 1909 ның 5 декабреннән номерлар яңабаштан куела, 1910 ның 27 ноябренә кадәр 56 саны нәшер ителә (1–56), ш.и. 4 се куш сан; 1911 нең 1 гыйнварыннан кабат басыла башлый, 1911 нең 25 декабренә кадәр 52 саны чыга (1–52), ш.и. 2 се — куш сан. Мөхәррире (1911 нең августыннан мөхәррир-нашир) — Изге Гурий борадәрлеге советы рәисе епископ *Андрей* (кенәз А.А.Ухтомский), асылда, мөхәррирдәш — О.П.Ермолаева. Журнал «чиркәү тормышы һәм әҗнәбиләр миссиясе үсеше мәсьәләләренә кагыла». Аның программасы үз эченә вәгазьләрне, әхлакый-догматик эчтәлектәге оригиналь һәм тәрҗемә мәкаләләрне, христиан диненең православие мәзһәбеннән башка динне пропагандалау хакындагы язмаларны; Изге Гурий борадәрлеге эшчәнлеге турындагы мәгълүматларны; «гомумән чиркәү тормышыннан хәбәрләр»не, Идел буе һәм башка православие миссиясе (ш.и. чит ил) турындагы язмаларны ала. Күпчелек материалларның авторы епископ Андрей була. Журналда профессорлар П.В.Знаменский, Н.Ф.Катанов, Я.Д.Коблов, Н.П.Остроумов, священниклар С.А.Багин, Т.А.Земляницкий, язучы, ислам белгече В.П.Череванский, журналист Б.П.Башинский һ.б.ның язмалары басыла. Мөселманлыкка, мәҗүсилеккә, таркатучыларга (иске дин тарафдарларына) каршы юнәлтелгән, католик һәм протестант миссияләргә, секталарга, «яңа» диннәргә багышланган миссионерлык мәкаләләре, Казан һәм Иркутск миссионер съездлары (1910) уздыру б-н бәйле материаллар, Изге синод фәрманнары, вәгазьләр, чиркәү иерархлары мәкаләләре, Казан уку-укыту округы идарәсе каршындагы тәрҗемәчелек комиссиясе балалары исемлеге, Идел буе халыклары телләрендә гыйбадәт китаплары басылу турында белдерүләр дөнья күрә, миссионерлык басмаларыннан күчерелгән язмалар, мөселман газеталары (ш.и. «Вакыт» һәм «Йолдыз») мәкаләләренең тәрҗемәләре, редакциягә килгән хатлар урнаштырыла. Керәшен татарларның исламга күчүенә каршы хәрәкәткә аерым урын бирелә: аларга епископ Андрейның үгет-нәсыйхәтләре һәм мөрәҗәгатьләре, «Казан епархиясе керәшен татар приходларының үзара христианлык ярдәмләшүе җәмгыяте» («Общества христианской взаимопомощи крещёно-татарских приходов Казанской епархии») эшчәнлеге турындагы документлар һәм мәгълүматлар һ.б. басыла. Бер үк вакытта *Ильминский системасына* каршы чыгучы карагруһчылар (В.Ф.*Залесский* һ.б.) б-н көчле бәхәсләр алып барыла, көчләп руслаштыру сәясәтенең киләчәге өметсез булуы исбатлана, аңа «әҗнәби» (туган) телләрдә рухи-миссионерлык агартуы каршы куела, дини һәм неославянофил позицияләрдән «рус миллилеге» доктринасы тәнкыйтьләнә. Мөселман дөньясы тормышы, яңа мөселман басмалары, хәйриячелек эшчәнлеге һәм татарларда мәгариф үсеше турындагы яңалыкларга; татар матбугатына күзәтүләргә, Идел буе халыклары этнографиясе буенча материалларга, урыннарда дини тормышны яктыртуга зур урын бирелә. Аеруча билгеле мәкаләләр арасында: «Ислам чыганаклары» («Источники Ислама»; миссионер У.С.Клэр-Тисдалл китабы бәяне), «Н.И.Ильминскийның басылмаган хатларыннан өземтәләр» («Из неизданных писем Н.И.Ильминского»), В.П.Череванскийның «Мөселманнарда мәхәллә җитәкчеләре һәм югары рухани затларны сайлау һәм билгеләү» («Избрание и назначение приходских и высших лиц мусульманского духовенства»), П.В.Знаменскийның «Әҗнәбиләр телләрендә руханилык хезмәте һәм әҗнәби руханилар хакында» («О богослужении на инородческих языках и о духовенстве из инородцев») һ.б. Ш.у. «гомуми характердагы» мәкаләләр; ш.и. Дәүләт Думасы әгъзалары (А.Л.Трегубов, С.Н.Максудов һ.б.) чыгышлары, «прогрессив мөселман төркеме» адресы буенча тәнкыйди мәкаләләр басыла. Исеме үзгәрү б-н, журналның Изге Гурий борадәрлеге хадимәләре акчасына чыга торган басма булуы турындагы күрсәтмә барлыкка килә. 1910 да 30 сан гомуми тышлык б-н «Идел буе әҗнәбиләрен агарту турында» («О просвещении приволжских инородцев») исемендә берләштерелә. Епископ Андрей Сухуми шәһәренә кафедрага күчерелгәч, журнал чыгудан туктый. 1912 дә ул анда «Сотрудник Закавказской миссии» ж-лын чыгаруга керешә.

*И.Е.Алексеев.*

**СО́ТЫЙ** посёлогы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ушма елгасы бассейнында урнашкан. Даими яшәүчеләр юк. Торак пункт буларак 1959 да теркәлә. Халык саны: 1958 дә — 127, 1970 тә — 109, 1979 да — 46, 1989 да — 27, 2002 дә — 16 кеше.

**СОФИ́Я СОБОРЫ́**, 1859–70 елларда Лаеш шәһәрендә төзелгән биш престоллы таш собор. 1937 дә ябылганнан соң, кинотеатр итеп файдаланыла. 2014 тә Казан епархиясенә тапшырыла һәм Никола соборы итеп үзгәртелә. Яңарту эшләре бара. 1999 да С.с. истәлегенә шул ук исем б-н Лаештагы Троицк хатын-кызлар монастыренең 1901–11 елларда арх. Ф.Н.Малиновский проекты буенча төзелгән, 1926 да монастырь б-н бергә ябылган һәм 1996 да диндарларга кире кайтарылган Троицк чиркәве изгеләштерелә.

Чаң манарасыз, симметрик күчәрле, биш гөмбәзле, дүрт баганалы, бер апсидалы бина. Храм үзе өсте шарсыман гөмбәз б-н ябылган, яктылык тәрәзәләре уелган биек үзәк барабан һәм дүрт ягына ябык тәрәзәле, сугансыман гөмбәзле дүрт барабан урнаштырылган ике рәт тәрәзәле дүрткырлык тәшкил итә. Көнчыгыш фасадта конхалы 3 апсида чыгып тора. Көнбатыштан ике кыеклы түбә б-н ябылган храм киңлегендәге, бер рәт тәрәзәле ашханә тоташкан. Храмның өч нефлы структурасы фасадлардагы рустланган терәкләр б-н аерылып тора. Храмның аркалы икенче рәт тәрәзәләре киль рәвешендәге профильле чыгынтылар б-н каймаланган. Көньяк һәм төньяк фасадлардагы ишек порталлары киль рәвешендәге архиволтлар б-н төгәлләнгән. Ашханәнең турыпочмаклы алты тәрәзәсе фасадларда ике ишек б-н бүленгән. Рус-Византия юнәлешендәге эклектика стилендә төзелгән дини архит-ра истәлеге. Кронштадт шәһәрендәге Никола диңгез соборы әлеге храмның прототибы булып тора.



Лаештагы София соборы. 1859–70.

*Әд.:* История Лаишевского края. Чебоксары, 1997; Республика Татарстан: православные памятники. К., 1998.

*Е.В.Липаков, В.П.Притыкин.*

**СОФРОНИ́ЦКИЙ** Павел Александрович (10.8.1910, Казан — 13.6.1997, Пермь ш.), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1962), РСФСРның атказ. геологы (1980). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1932), «Востокнефть» трестының геол. картага төшерү партиясе башлыгы булып эшли. 1946–52 елларда «Пермьнефть» берләшмәсенең геол. раз-

ведка конторасында баш геолог. 1949 дан Пермь ун-тында, тарихи геол. һәм палеонтология каф. мөдире (1952–97), проф.-консультант (1981 дән). Хезмәтләре геологиягә, Көнчыгыш Рус платформасының нефтьлелегенә карый. С. — ТАССР һәм чиктәш терр-яләрнең геол. һәм тектоник карталарын төзүчеләрнең берсе. Урал-Идел буеның көнчыгыш районнарында углеводородларны эзләү перспективаларын нигезли, соңыннан биредә 46 чыганак ачыла, шуларның берсенә аның исеме бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Материалы по геологии Волжско-Камского края. К., 1978 (автордаш).

*Әд.:* Профессору П.А.Софроницкому 75 // Геология нефти и газа. 1986. № 4.

**СОФРО́НОВ** Валерий Викторович (26.8.1946, Казан), педиатр, мед. фән. д-ры (2000), проф. (2002). Благовещенск мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1970), шунда ук балалар авырулары кафедрасында (бүленеп, 1973–74 елларда Ленинград педиатрия мед. ин-тында) эшли. 1979 дан Семипалатинск мед. ин-тында. 1994 тән Казанда, Респ-ка гаилә, ана һәм балалар сәламәтлеген саклау үзәгенең перинаталь бүлегендә. 2001 дән Казан мед. ин-тының балалар авырулары каф. мөдире. Хезмәтләре яңа туган һәм бер яшькәчә балаларның сәламәтлеге формалашу барышында функциональ системалар параметрларын өйрәнүгә, кече яшьтәге балалар сәламәтлегенә карый.

Х е з м.: Клиническое значение цитофотометрических показателей ядерной ДНК лимфоцитов периферической крови новорождённых различного гестационного возраста // Педиатрия. 2001. № 3 (автордаш); Иммунологические особенности язвенной болезни двенадцатиперстной кишки у детей, осложнённой инвазивным кандидозом // Аллергия и иммунология. 2004. Т. 5, № 2; Детские болезни: Учеб. пособие. К., 2005 (автордаш).

**СОФРО́НОВ** Владимир Георгиевич (20.8.1946, Казан), зоогигиенист, вет. токсикологы, вет. фән. д-ры (1995), проф. (2000), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2001). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1970), шунда ук эшли (бүленеп), зоогигиена каф. мөдире (1999 елдан). 1985–99 да Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү вет. ин-тында, техноген экотоксикантлар лаб-ясе мөдире (1994–99). Фәнни тикшеренүләре терлекләрнең авыр металлар, диоксин һәм фторорганик кушылмалар б-н агулануы очракларында куллану өчен зарарсызландыручы дәвалау-профилактика чаралары уйлап табу өлкәсенә; нәорганик кушылмалар һәм полифермент препаратлар комплексының терлек организмына тәэсирен вет.-гигиена ягыннан бәяләүгә карый.

Х е з м.: Содержание тяжёлых металлов в почвах и кормах регионов РТ // Ветеринарный врач. 2000. № 2; Ферментирование боенских отходов // Птицеводство. 2005. № 5.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**«СОЦИАЛИ́ЗМ ЮЛЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Свердловск өлкә ком-ты органы. 1919 елның 23 гыйнварыннан Вятка шәһәрендә, 1919 ның 12 августыннан 1939 ның 28 февраленә кадәр Свердловск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 3111 саны чыга. Исеме үзгәрә: 1925 нең 14 августына кадәр — «Коммунист», 1930 ның 18 маена кадәр «Сабан һәм чүкеч», алга таба — «С.ю.». Совет чорында татар телендә чыга торган иң зур өлкә газеталарының берсе. 1932 дән көн саен басыла башлый. Оешкан вакытта газета Эшче һәм солдат депутатлары советының Вятка губерна башкарма ком-ты татар-башкорт секциясе органы була. Аны оештыручылар — Пермь шәһәренең Вяткага килгән Мөселман эшләре буенча комис-т җитәкчеләре К.Мохтаров, Х.Мәүлетов, М.Борындыков һәм 1918 дә Пермьдә нәшер ителгән «Кызыл Урал» кызылармиячеләр г-тасы хезмәткәрләре. 10 нчы саныннан (1919 ның 8 апреленнән) Көнчыгыш фронтның 3 нче армиясе сәяси бүлеге органы була, 49 нчы саннан (1920 нең 30 гыйнвары) — 1 нче Хезмәт армиясенең сәяси комиссиясе, 73 нче саннан (1920 нең 9 июле) — РКП(б)ның Урал өлкә ком-ты каршындагы татар-башкорт бюросы, 1925 нең 14 августыннан 1934 нең 24 гыйнварына кадәр — ВКП(б)ның Урал өлкә ком-ты органы. Мөхәррирләре — К.Мохтаров, Н.Бәхтияров, Ш.Абашев, Х.Ишбулатов, С.Садыйков, И.Галиев, С.Нураев, С.Хәсәнкәев, С.Мөлеков. Газета б-н А.Әхмәтов, Х.Биктимеров, М.Борындыков, С.Вәлиев, М.Гайнуллин, Г.Гатауллин (Апуш), Н.Динмөхәммәтов, Г.Иделле (Усманов), Х.Мәүлетов, Ш.Маннур, И.Наумов, И.Туктаров, М.Уразмөхәммәтов, Г.Үтәгәнов, Ш.Хәбибуллин, С.Хәйруллин (Камский), И.Хамматов һ.б. хезмәттәшлек итә. «С.ю.» Урал өлкәсенең, илнең иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм мәдәни тормышын киң яктырта (Урал татар эшчеләре һәм крәстияннәре тормышы турында зур материал бирә).

Газетаның даими чыгып барган «Әдәби сәхифәләр»ендә Урал төбәгенең яшь татар язучылары, шагыйрь һәм журналистлары Г.Абдуллин, Х.Әминев, М.Афзалова, А.Әхмәтов, Х.Быков, З.Җиһаншин, Ш.Искәндәров, Ф.Кәримов-Азналы, Ш.Маннур, Г.Теләшев, Г.Иделле, И.Яһүдин һ.б.ның хикәя, шигырь һәм очерклары басыла. Газета Урал пролетар язучылары ассоциациясе татар-башкорт секциясе авторлары б-н актив хезмәттәшлек итә. 1924–27 дә редакция рәсемле-әдәби, фәнни-сәяси һәм сатирик «Шәпи агай» популяр ж-лын (28 сан) чыгара. 1932–33 тә Свердловск шәһәрендә «Культура өчен», «Уралмаш ударнигы», Кизел шәһәрендә «Күмер өчен» һәм «Урал кочегаркасы» кушымталары нәшер ителә.

*Әд.:* «Сабан-чүкеч»нең 10 елы. Свердловск, 1929; «Социализм юлы» газетасының 15 еллыгына карата кайбер материаллар. Свердловск, 1934.

*Т.М.Насыйров.*

**СОЦИАЛИ́СТИК ОЕШМАЛА́Р БЕРЛЕГЕ́** (Соц. блок), сәяси-иҗтимагый оешма. 1917 елның 18 октябрендә Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларының Казан советындагы сул эсерларга һәм большевикларга каршы торучы урта социалистларны (уң эсерлар, меньшевиклар) берләштерү өчен оеша. Бу эшнең башында Казан хәрби округында Вакытлы хөкүмәт комиссары Е.П.*Калинин* тора. Берлек җитәкчелегенә меньшевиклар Ю.П.Денике, Б.Н.Нелидов, К.М.Остров; уң эсерлар Б.В.Бартольд, М.С.Бухов (Казан шәһәр милициясе башлыгы), В.И.Якобсон, Бөтенроссия мөселман хәрби советыннан И.С.Алкин керә. Берлекнең төп максаты советларның хакимияткә килүенә юл куймаска омтылу була. Хәрби хакимиятләр тарафыннан С.о.б. оешуга Казан советының өлкән яшьтәге солдатларны демобилизацияләү турындагы карарлары (бу Вакытлы хөкүмәткә турыдан-туры буйсынмауны аңлата), ш.у. Хәрби министрлыкның сәяси идарә башлыгы В.В.Шерның Казан советы б-н кораллы көрәш алдында тукталып калмаска дигән өндәмәсе (1917 нең 18 октябрендә Казан Хәрби округы командующие тарафыннан бирелә) өстәмә сәбәп булып тора. Оешкан көндә үк Берлек җыены хакимият советлар тарафыннан басып алынган очракта аның «Социалистик оешмалар берлеге ягыннан катгый каршылыкка очраячагы» турында карар чыгара. Е.П.Калининның катгый таләбе б-н Берлек каршында хәрби ком-т төзелә, аның б-н Берлекнең элеккеге рәисе П.С.Галанов җитәкчелек итә. 1917 нең 23 октябреннән 24 октябренә каршы төндә хәрби ком-т РСДРП(б)ның Казан ком-ты җитәкчеләре К.Я.*Грасис* б-н Н.Е.*Ершовны* «гаскәрләрне баш күтәрергә котырту»да һәм революцион гарнизонны коралсызландыруда (утырышта Е.П.Калинин, П.С.Галанов, К.Б.Поплавский, М.С.Бухов катнаша) гаепләп кулга алырга ниятли. Кулга алу һәм коралсызландыру омтылышлары *Казанда 1917 елгы Октябрь кораллы баш күтәрелешенә* (24–26 октябрь) китерә. 1917 нең 26 октябрь иртәсендә, юнкерлар капитуляцияләве, баш күтәргән солдатларның җиңүе һәм хакимиятнең советлар кулына күчүе турында хәбәр иткәннән соң, С.о.б. эшләүдән туктый.

*С.И.Ионенко.*

**«СОЦИАЛИ́СТИК ТАТАРСТА́Н»**, газета; к. «*Ватаным Татарстан*».

**СОЦИАЛИ́СТИК ХЕЗМӘ́Т ГЕРОЕ́**, 1938–91 елларда СССРда иң югары дәрәҗәле мактаулы исем. Хуҗалык һәм мәдәният өлкәсендә ирешелгән аеруча зур казанышлар өчен бирелә. СССР ЮС Президиумының 1938 ел 22 декабрь карары нигезендә гамәлгә кертелә. Сәнәгать, а.х., мәдәният өлкәләрендәге аеруча күренекле новаторлык эшчәнлекләре б-н илнең куәтен һәм данын үстерүгә булышлык иткән кешеләргә СССР ЮС Президиумы тарафыннан бирелә. Геройларга СССРның иң югары бүләге — Ленин ордены һәм СССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы тапшырыла. С.Х.Г. исеменә лаек булган шәхесләрне махсус бүләкләү максатыннан СССР



Социалистик Хезмәт Героеның «Урак һәм Чүкеч» медале.

ЮС Президиумының 1940 ел 22 май карары нигезендә «Урак һәм Чүкеч» алтын медале булдырыла, ул Ленин ордены һәм грамота б-н бергә тапшырыла; яңа зур казанышларга ирешкәннәр 2 нче «Урак һәм Чүкеч» медале һәм грамота б-н бүләкләнә. Ике тапкыр С.Х.Г. булганнарга, күренекле казанышларын хөрмәтләү йөзеннән, туган якларында бронза бюст куела. ТАССРда С.Х.Г. исеменә 201 кеше лаек була, шуның 93 е — татар. Респ-кадан читтә яшәүче татарлар арасында С.Х.Г. исемен йөртүчеләр — 40 тан артык кеше. Татарстанда туып үскән П.В.Дементьев (1941 дән СССР авиация сәнәгате халык комиссарының 1 нче урынбасары) һәм В.Г.Садовников (1966 дан Воткинск машиналар төзү з-ды директоры) С.Х.Г. исеменә ике тапкыр лаек булалар (Кушымтадагы исемлекне кара).

Чыг.: Сборник законов СССР и указов Президиума ВС СССР, 1938–1961. М., 1961; Ведомости ВС СССР. 1962. № 13.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии: Сб. статей. К., 1948; Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978). К., 1980; Герои Социалистического Труда Татарстана. К., 1984; Герои Социалистического Труда. М., 1988.

*М.З.Хәбибуллин.*

**«СОЦИАЛИСТИ́ЧЕСКАЯ ИНДУСТРИ́Я» НА СТРОЙ́ТЕЛЬСТВЕ КА́МСКОГО АВТОЗАВО́ДА»** («Социалистик индустрия» Кама автозаводы төзелешендә»), атналык икътисади газета. КПСС ҮКның махсус басмасы. 1971–76 елларда Чаллы шәһәрендә рус телендә нәшер ителә. Мөхәррире — Ю.А.Косов. Газетада КАМАЗдагы төзелеш эшләренең барышы тәфсилләп яктыртыла.

**«СОЦИАЛИСТИ́ЧЕСКИЙ ТАТАРСТА́Н»** («Социалистик Татарстан»), айлык сәяси-икътисади журнал. ТАССР ҮБК һәм ХКС органы. «*Социалистическое хозяйство Татарстана*» ж-лы дәвамчысы. 1935 елның июненнән 1937 нең июленә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә. Төрле елллардагы мөхәррирләре — Т.Т.Эюпов, Я.Ф.Ефимов, Р.Ю.Алкин, В.М.Стам. Баш мәкаләләрнең күп өлеше ТАССР ҮБК Президиумы рәисе Г.Г.*Байчурин* һәм ТАССР ХКС рәисе К.А.*Абрамов* тарафыннан языла. Актив авторлары



«Социалистический Татарстан» журналы.

арасында — А.Аитов, А.М.Габдуллин, Ш.В.Галиев, М.Ибраһимов, М.И.Исхаков, В.М.Корольчук, Х.Мәһдиев, Н.И.Тихонов. Журналда Татарстандагы хуҗалык, дәүләт һәм мәдәният төзелешенең хәле турындагы хисаплар һәм күзәтүләр, директив күрсәтмәләр, ш.и. икътисад өлкәсендә «корткычлык», «троцкистларның мәкерле казынулары» б-н көрәше мәсьәләсенә караган күрсәтмәләр басыла. «ТАССР Халык комиссарлары советында» («В Совнаркоме ТАССР») даими сәхифәсе чыгып килә. Халык хуҗалыгын планлаштыру, дәүләт бюджеты үтәлеше, житештерүче көчләрнең урнашуы, фән һәм техника, стахановчылар хәрәкәте, шәһәр хуҗалыгы үсеше, төзекләндерү һ.б. мәсьәләләр карала. ТАССР атласын төзү (1935, № 1–2) эшләренә багышланган материаллар кызыксыну уята. Акрынлап журналның эчтәлеге саега башлый, һәм сәяси репрессияләр, ш.и. ТАССРның икътисади җитәкчелегенә каршы репрессияләр көчәю шартларында чыгудан туктый.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«СОЦИАЛИСТИ́ЧЕСКОЕ ХОЗЯ́ЙСТВО ТАТАРСТА́НА»** («Татарстанның социалистик хуҗалыгы»), айлык иҗтимагый-икътисади журнал. 1921 елда ТАССР ХКС һәм Татарстан профсоюзлар советы органы (айга 2 тапкыр чыга), 1922 дән — ТАССР ХКС каршындагы Икътисади совет, 1926 дан ТАССР Дәүләт план ком-ты журналы. 1921–34 тә Казанда рус телендә басыла. Исеме үзгәрә: 1921 дә — «Труд и хозяйство», 1930 ның апреленнән — «С.х.Т.». Журналны басмага ТАССР ХКСның мәгълүмат-нәшрият бүлеге һәм ТАССРның икътисад халык комиссариатлары әзерли. Төрле елллардагы мөхәррирләре — А.Н.Злобин, М.А.Эглит, В.М.Горин, Н.-Б.З.*Векслин*, А.Пусэп, Д.Белик, А.А.Терский, С.З.Эскин. Актив авторлары арасында — М.И.Борисов, Б.Е.Будде, И.М.Бурдянский, В.Т.Дитякин, К.П.Дьяконов, В.В.Егерев, Т.Г.Ефимов, А.Н.Злобин, В.Мансуров, К.Г.Мохтаров, И.Ф.Победоносцев, В.Ф.Смолин, И.Сотонин, А.А.Труфанов, Ю.Фемидин, М.А.Хәсәнов һ.б. Гражданнар сугышыннан соңгы халык хуҗалыгын торгызу һәм Татарстан икътисадын үстерү мәсьәләләре киң яктыртыла. Материалларда НЭП сәясәтенең гамәлгә ашырылуы анализлана, сәнәгать һәм а.х.дагы үзгәрешләр тасвирлана. Журналдагы язмаларга карап, базар реформаларының кысылуы, икътисад б-н идарә итүнең команда-бюрократик принциплары кертелү, 1920 еллар ахырында — 1930 еллар башында икътисад теориясендә плюрализм һәм башкача фикер йөртүнең эзәрлекләнүе процессларын күзәтергә була. «Бюллетень Государственной плановой комиссии РТ» кушымтасы чыгарыла. Мәскәүнең «Красная печать» ж-лы 1927 ел өчен икътисади матбугатны күзәтүдә «С.х.Т.»ны милли респ-калар арасында чыга торган иң яхшы икътисади журнал дип атый. Ш.у.к. «*Социалистический Татарстан*».

*Әд.:* Ковалевский Н. Как построить сеть экономических журналов // Красная печать. 1927. № 9.

*Р.А.Айнетдинов.*

**СОЦИАЛИСТЛА́Р БЛОГЫ́**, к. *Социалистик оешмалар берлеге.*

**«СОЦИАЛИ́СТ-РЕВОЛЮЦИОНЕ́Р»**, иҗтимагый-сәяси газета. Социалист-революционерлар партиясенең Казан ком-ты органы. 1917 елның 7 маеннан 25 сентябренә кадәр Казанда рус телендә атнага 2 тапкыр нәшер ителә, барысы 37 саны чыга. Мөхәррире — К.Архангельский. Авторлары арасында — А.Белоусов, П.Бензаман, Ю.Богданов, П.Бунаков, Ф.Волховской, В.Чернов (псевд. Ю.Горденин), П.Голованов, Г.Дорофеев, И.Заплатин, И.Званский, М.Исакович, Д.Ишимский, Б.Коварный, В.Коновалов, А.Кудряшов, Ф.Лебедев, Ф.Пачков, Г.Ратнер, Ш.Сапожников, Н.Святницкий, А.Синицын, Е.Трупп, В.Трутовский, А.Турбинер, А.Устинов, П.Фешин, К.Шнуровский, Д.Эльмень һ.б. Газета «Крестьянская и рабочая газета» дигән өстәмә баш һәм «Көрәштә генә үз хокукыңны табарсың» девизы б-н чыга. Эсерлар программасының төп кагыйдәләрен пропагандалый, «халык б-н бергә җир һәм ирек, барлык кешеләр тигезлеге һәм бәхете, социализм өчен көрәш» идеяләрен яклап чыгыш ясый. Милләтләрнең үзбилгеләнү хокукы һәм Россиянең федератив-демократик респ-кага әверелүе ягында тора. Редакция башка соц. газета — большевикларның Казан ком-ты органы булган «*Рабочий*» г-тасы басыла башлауны хуплый. Газета Вакытлы хөкүмәткә, аның җиңгәнчегә кадәр сугышны дәвам итү сәясәтенә кискен мөнәсәбәттә тора. 1917 нең июлендә Петроградтагы кан коюны Вакытлы хөкүмәт составыннан үз ирекләре б-н чыккан кадетлар җаваплылыгында калдыра.«С.-р.» генерал Л.Г.Корнилов фетнәсен кискен гаепли. Редакция эсерларның 1917 нең март ахырында аерылып чыккан Казан иске ком-тының (уңнар) таркату эшчәнлегеннән зарлана. 1917 нең 16 июлендә «С.-р.»да эсерлар партиясенең ҮКна гомумгуберна конференциясе чакыру юлы б-н иске һәм яшь ком-тлар арасындагы фикер каршылыгын бетерүгә катнашу тәкъдиме б-н чыккан мөрәҗәгате басыла. 1917 нең 13 сентябрендә аны үткәргәннән соң, бердәм Казан губерна һәм шәһәр ком-ты б-н уртак басма орган оештыру турында карар кабул ителә. 1917 нең 29 сентябрендә, «С.-р.»ны «*Известия Казанского губернского совета крестьянских депутатов*» г-тасы б-н берләштергәч, «*За землю и волю*» г-тасы чыга башлый. Иске ком-тның «*Голос труда*» г-тасы редакциясе берләштерүгә тискәре карый, үз басмасын мөстәкыйль рәвештә чыгаруны дәвам итә.

*Т.М.Насыйров.*

**СОЦИАЛИ́СТ-РЕВОЛЮЦИОНЕРЛА́Р ПА́РТИЯСЕ** (социалист-революционерлар, эсерлар), 1901–23 елларда Россиядәге сәяси партия. Төп програм-таләпләре: самодержавиене бәреп төшерү, демократик респ-ка төзү, хокуклар һәм ирекләрне гарантияләү, 8 сәгатьлек эш көненә ирешү, җирләрне соц. милеккә әверелдерү һ.б. Көрәшнең яшерен эш итүдән коралллы баш күтәрүгә кадәр төрле ысулларын кулланалар, партия тактикасында террор да зур урын алып тора. Җитәкчелә-

ре — В.М.Чернов, М.Р.Гоц, Н.Д.Авксентьев һ.б. 1905–07 еллардагы рев-ция чорында эсерлар Мәскәү (1905 нең декабре), Кронштадт, Свеаборг (1906 ның җәе) һ.б. җирләрдә узган коралы бәрелешләрдә катнашалар. Партия вәкилләре Эшче депутатлары советы, Бөтенроссия крәстияннәр берлеге составына керәләр. 1906 да партиядән үтә сул фракция — максималистлар аерылып чыга. 1907–16 да С.-р.п. идея һәм оештыру ягыннан кризис кичерә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң эсерлар Вакытлы хөкүмәт составына керәләр, Бөтенроссия ҮБКда, Крәстиян депутатлары советы Башкарма ком-тында, Россия Респ-касының Вакытлы советында (парламентка кадәр) җитәкче вазифасын башкаралар, Учредительләр җыенына вәкилләр сайлауда күпчелекне тәшкил итәләр. 1917 дә партиянең сул канаты мөстәкыйль *сул эсерлар* партиясен оештыра. Учредительләр җыенына вәкилләр сайлауда С.-р.п. күпчелек урынны ала.

Казан губернасында беренче С.-р.п. оешмалары, ш.и. 1905 тә ком-т буларак үзгәртелгән Казан губерна оешмасы да, 1902–03 тә барлыкка килә. 1904 нең мартында Казан ун-ты студентлары Г.А.Гиршфельд һәм А.С.Поляков Казан социалист-революционерлар төркемен (17 кеше) оештыралар. Идел буендагы башка оешмалар б-н элемтә урнаштырыла, эсерлар партиясенең крәстиян сугышчан дружиналары уставын эшләгән Казан губерна хәрби ком-ты төзелә. 1904 нең маенда, 14 әгъзасы кулга алыну сәбәпле, оешма эшләүдән туктый. 1905 нең октябрендә П.Л.*Драверт* җитәкләгән Казан губерна ком-ты Казандагы коралы күтәрелештә катнаша, аның вәкилләре *Казан шәһәр коммунасы* составына керә. Алар, үз мәнфәгатьләрен күздә тотып, «*Волжский вестник*», «*Дневник Казани*», «*Крестьянская газета*» г-таларыннан, «*Метеор*» ж-лыннан файдаланалар. 1906 да хәрби оешма, 1907 дә сугышчан оешма (Л.Н.Коротнева, А.И.Кудрявцев, С.Л.Маслов, В.А.Тотауров, А.И.Целин һ.б. була) төзелә. 1907 дә Казан эсерлары Казан хәрби округы командующие А.Г.Сандецкийга каршы өч тапкыр террорлык акты оештырырга омтылалар, вице-губернатор Д.Д.Кобеконы үтермәкче булалар. 1905 тә Казанда татар яшьләре тарафыннан С.-р.п.нең милли ком-ты оеша (к. «*Таңчылар*»), аның составында Г.*Исхакый*, Ф.*Туктаров*, С.Рәмиев, Ш.Мөхәммәдьяров була. 1906 да Казан ун-ты студенты В.Паленин һәм Пенза сәнгать мәктәбенең элекке шәкерте В.Доринский Казан эсер-максималистлар оешмасы төзиләр, бу оешма шактый гына экспроприация үткәрә: почтаны, шәраб базларын талый һ.б. 1907 дә төркем әгъзалары кулга алына.

Реакция елларында полиция күп кенә эсер оешмаларының эзенә төшә, аларның әгъзалары кулга алына. Казан губернасында эсерларның аерым-аерым берничә түгәрәге эшли, алар актив эшчәнлек алып бармый. Беренче бөтендөнья сугышы елларында эсер студентлар арасында эсер-интернационалистлар В.И.Жилинский, Н.П.Пономарёв, К.Ю.Шнуровский һ.б.ның йогынтысы зур була. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң нәкъ менә алар эсерлар партиясенең Казан губерна ком-тын төзүдә (1917 нең марты) инициатива белдерәләр. Ком-т оешып озак та үтми, аның әгъзалары арасында сугыш һәм тынычлык мәсьәләсенә карата фикер каршылыклары килеп чыга. Конфликт нәтиҗәсендә партиянең гомуми җыелышында радикаль карашлы эсерлар В.П.*Брауде*, И.А.*Майоров*, К.Ю.Шнуровский һ.б. инициативасы б-н ком-т яңадан сайлана. Аңа Казан эсер-интернационалистлар һәм максималистлар оешмасы әгъзалары керә, 1917 нең апреленнән кече ком-тның секретаре В.П.Брауде була. Зур ком-тка керүче эсерлар, гомуми җыелыш карарының тулы хокуклы булмавы турында әйтеп, аңа буйсынудан баш тарталар, җыелышны ташлап чыгып китәләр һәм үз ком-тларын оештырулары турында игълан итәләр. Шул рәвешчә С.-р.п.ннән сул эсерлар аерылып чыгудан бик күп элек Казан социалист-революционерлары арасында уң һәм сулга бүленү күзәтелә башлый. Сул эсерлар «Социалист-революционер» г-тасын чыгаралар.

1917 нең 22 сентябрендә С.-р.п. ҮКнда Д.Ф.Раковның Казанда партияләр таркалу хакындагы чыгышы тыңлана, аның нигезендә гомумшәһәр конференциясендә сайланган Казан шәһәр ком-тының (1917 нең 12 сент.) һәм губерна конференциясендә сайланган Казан губерна ком-тының (1917 нең 13 сент.) тулы вәкаләткә ия булулары турында карар кабул ителә. 1917 дә эсерлар меньшевиклар б-н берлектә Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларының Казан советында күпчелекне тәшкил итәләр. 11 майда Крәстиян депутатларының Казан губерна советы рәисе итеп кече ком-т әгъзасы А.Л.*Колегаев* сайлана. Казан шәһәр думасына сайлауларда (1917 нең 8 окт.) эсерлар — 14,9%, мөселман социалистлар, тулаем алганда, (ш.и. эсерлар да) 23,9% тавыш җыя. Казан губернасында Учредительләр җыенына сайлауларда эсерлар өчен якынча 270 мең кеше тавыш бирә, 5 депутат сайлана.

1917 нең 18 октябрендә уң эсерлар меньшевиклар б-н берләшеп, *Социалистик оешмалар берлеге*н төзиләр, Окт. рев-циясеннән соң сов. хакимиятенә каршы чыгалар, большевикларга каршы төрле акцияләрдә һәм алар сәясәтен танымаган оешмаларда катнашалар (*Учредительләр җыены әгъзалары комитеты* һ.б.). Шуңа да карамастан, 1918 нең көзенә кадәр партия яшерен рәвештә эшли: кайбер эсерлар сов. хакимияте органнарында хезмәт итәләр. 1918 ел башыннан большевиклар хөкүмәте тарафыннан эсерларга каршы репрессияләр башлана, 1918 нең февралендә эсерларның — «*Крестьянская жизнь*» (элекке «Крестьянская газета»), шул ук елның мартында «*Трудовой путь*» г-талары чыгудан туктый. 1918 нең 14 июнендә Бөтенроссия ҮБК Декреты нигезендә меньшевиклар һәм эсерлар партияләре вәкилләре (уң һәм үзәк) Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларының барлык советларыннан да чыгарылалар. Казанда Г.Мартюшин һәм С.Н.Каллистов җитәкчелегендәге уң эсерларга 4 нче Казан губерна крәстиян депутатлары съездында катнашу тыелган була. Оешмалар саны кискен кими, кайбер эсерлар, нигездә, сул эсерлар большевиклар партиясенә күчә. С.-р.п.нең 8 нче Советында (Мәскәү, 1918 нең мае) коралны күтәрелешкә әзерләнү мөһимлеге турында карар кабул ителә. Совет эшендә Казанның уң эсерлар ком-ты рәисе С.Н.Каллистов та катнаша. 1918 нең август–сентябрендә С.-р.п.нең Казан оешмасы Учредительләр җыены әгъзалары ком-ты хакимиятен хуплый. 9 августта эсерларның «*Народное дело*» г-тасы яңадан басылып чыга башлый. Казан КОМУЧ Халык армиясе тарафыннан басып алынганнан соң (1918 нең 7 августы), Казан эсерлар ком-ты партиянең корал б-н эш итә белүче барлык әгъзаларын да Халык армиясе сафларына басарга мәҗбүр итү турында карар кабул итә. 1918 нең көзеннән Казан оешмасы яшерен эш итүгә күчә һәм гамәлдә эшчәнлеген туктата. Эсерларның бер өлеше Халык армиясе б-н китә. 1921–23 еллар дәвамында эсерлар бөтен җирдә диярлек кооперация һәм профсоюзларның җитәкчелек органнарыннан кысрыкланып чыгарыла. 1923 тә С.-р.п. эшчәнлеге тыела. 1923 нең 25 декабрендә эсерлар партиясенең элекке әгъзаларының Бөтентатар конференциясендә (Казан) барлык элекке социалист-революционерларны «мәгънәсез битарафлык халәтеннән чыгарга һәм III Интернационал байрагы астында Россия Коммунистлар партиясе сафларына берләшергә» өндәгән карар кабул ителә. 1930 елларда С.-р.п.нең элекке әгъзалары репрессияләргә дучар ителәләр. 1936 ның ноябрендә СССР Эчке эшләр халык комиссары Н.И.Ежов күрсәтмәләрнең берсендә эсерларның барлык төркемнәрен дә юкка чыгарырга боера. 1937 дә СССРда элекке эсерлардан якынча 25 мең кеше репрессияләнә.

*Әд.:* Каллистов С.Н. Казанская организация П.С.Р. (правых) и власть Комуча в Казани // Борьба за Казань. К., 1924; Литвин А.А. Общественно-политическое движение в Поволжье. Конец XIX — начало XX вв.: Российская историография. К., 2003; Стариков С.В. Левые социалисты в Великой Российской революции: Март 1917 – июль 1918 гг. (на материалах Поволжья). Йошкар-Ола, 2004; Хабибрахманова А.В. Деятельность политических партий в Казани в годы Первой российской революции. К., 2006; Суслов А.Ю. Социалисты-революционеры в Советской России: Источники и историография. К., 2007.

*А.Ю.Суслов.*

**СОЦИА́ЛЬ ГИГИЕ́НА**, гигиенаның халык сәламәтлеге торышына социаль факторларның йогынтысын, социаль авыруларны; туу һәм үлем (гомуми үлем һәм балалар үлеме), гомер озынлыгы б-н бәйле проблемаларны; халыкка дәвалау-профилактика ярдәме күрсәтүне һәм эпидемияләргә каршы көрәшне оештыру мәсьәләләрен өйрәнүче бүлеге. С.г. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында, Россиянең мед. уку йортларында махсус лекция курслары кертелү, С.г. кафедралары оештырылу б-н бергә барган фәнни тикшеренүләр процессында формалаша. 1874 елдан Казан ун-тының мед. ф-ты студентлары өчен мед. статистикасы һәм мед. географиясе буенча лекцияләр укыла башлый (укытучы П.А.Песков). 1923 тән ун-тта, Россиядә өченче бу-

лып, С.г. каф. оештырыла (мөдире В.В.*Милославский*, 1928 дән — М.М.Гран). М.М.Гран мед. тарихы буенча лекцияләр курсы кертә, сан.-гигиена ф-ты булдыру башлангычы б-н чыга. 1926 да ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-ты каршында, респ-ка халкының сәламәтлегe торышын өйрәнү максатыннан, С.г. ин-ты оештырыла; ГИДУВта С.г. һәм сәламәтлек саклау кафедрасы ачыла (мөдире М.А.Дыхно). 1930 еллар Казан галим-гигиена белгечләренең (Ф.Г.Мөхәммәдъяров, В.В.Трейман) хезмәтләре респ-ка халкының төрле төркемнәренең сәламәтлегe торышына, йогышлы авыруларны кисәтү мәсьәләләренә кагылышлы тикшеренүләрне үз эченә ала.

Совет хакимиятенең беренче дистә елларында туберкулёз, трахома, корчаңгы, йогышлы эчәк авыруларын, венерик һәм башка авыруларны юк итү бурычы куела һәм хәл ителә. 1920 дә респ-када беренче санатория учреждениесе — туберкулёз б-н авыручыларны дәвалаучы «*Каменка*» санаторие эшли башлый; Е.М.Лепский башлангычында туберкулёз б-н авыручы балалар өчен ике Балалар йорты ачыла; 1922 дә ш.у. балалар өчен «*Обсерватория*» сөяк туберкулёзы санаторие, Казан хәрби госпиталендә туберкулёз б-н авыручылар өчен махсус бүлек оештырыла, Иж-Бубый авылында (Әгерҗе р-ны) кымыз дәваханәсе торгызыла. Респ-када туберкулёз диспансерлары, ш.и. Респ-ка үзәк туберкулёз диспансеры (1921 дә ачыла) булдырыла, аларда авырулар диспансеризация уза һәм дәвалануны дәвам итәргә юллана. 1950–60 ларда онкология, трахома, зоб, психоневрология диспансерлары һ.б. ачыла (к. *Диспансерлар*). ГИДУВ каршындагы сәламәтлек саклау өлкәсе җитәкче кадрлары әзерләү өчен дипломнан соңгы белем бирү системасында проф. Т.Д.Эпштейнның махсус лекция курсларында (1931) С.г. мәсьәләләренә зур игътибар бирелә. ГИДУВның С.г. һәм сәламәтлек саклауны оештыру каф. һәм Казан мед. ин-ты галимнәре тарафыннан трахома һәм аңа каршы көрәш (Ю.Юшкин, В.Д.Смирнов, 1950 еллар), балалар үлеме (Н.А.Фролов, 1950 еллар; В.Ю.Альбицкий, 1990 еллар), рахитка каршы көрәш (Р.И.Еникиев, 1950 еллар), мед. демографиясе, авыруларны кисәтү (Т.Д.Эпштейн, 1960 еллар; А.Х.Яруллин, 1990), аллергия авыруларын мед.-социаль кисәтү (Ә.Н.Галиуллин, Ф.В.Хуҗиханов, 1990 еллар) һ.б. актуаль фәнни юнәлешләрдә тикшеренүләр алып барыла.

1990 еллардан Казан гигиена белгечләре аеруча киң таралган социаль әһәмиятле авыруларны өйрәнү буенча интенсив эш алып баралар. Яман шеш, гепатит, туберкулёз, аллергия һәм башка авыруларны дәвалау һәм кисәтү мәсьәләләре иң мөһимнәрдән санала.

*Әд.:* Трейман В.В. Охрана здоровья трудящихся Татарской АССР до и после Великой Октябрьской Социалистической Революции: Дис. ... К., 1955; Низамов И.Г. Кафедре общественного здоровья и управления здравоохранением Казанской государственной медицинской академии 75 лет. К., 2001.

*Ә.Н.Галиуллин, Р.Г.Исхакова.*

**СОЦИА́ЛЬ МЕДИЦИ́НА**, к. *Социаль гигиена.*

**СОЦИА́ЛЬ-ИКЪТИСА́Д ҺӘМ ХОКУ́К ФӘННӘРЕ́ ИНСТИТУТЫ́**, ТР ФАнең фәнни-тикшеренү ин-ты. 1993 елның апрелендә ТР МК карары һәм ТР Президенты Указы б-н оештырыла. «ТРда базар мөнәсәбәтләре үсешендә социаль-икътисади, хокукый һәм дини алшартлар», 1995 тән — «ТРның социаль-икътисади, хокукый һәм сәяси моделе: генезис һәм перспективалары», 2001 дән — «ТРның социаль-икътисади, хокукый һәм сәяси үсешен теоретик-методологик тәэмин итү» фәнни юнәлешләрен эшли. Институт составында 4 бүлек, 1 үзәк һәм 2 төркем бар: фәнни тикшеренүләрне координацияләү; мәгълүмат җыю, эшкәртү һәм анализлау. Социол. бүлеге — социаль модернизация шартларында халыкның яшәү сыйфаты үзгәрешен, икътисад бүлеге — федератив дәүләт барлыкка килү чорында төбәктәге икътисади процессլар эволюциясен, хокук һәм политология бүлеге — РФдә демократик дәүләт барлыкка килүнең сәяси-хокукый аспектларын, филос. бүлеге — үзгәрешләр барган җәмгыятьтә социаль процесслар өлкәсендәге тикшеренүләрнең теоретик-методологик нигезләрен, социаль тикшеренүләр үзәге ТРда төбәккә хас үзгәрешләр барышында социаль тәңгәллек барлыкка килүне өйрәнә. 2004 кә 32 фәнни хезмәткәр, ш.и. РМА һәм ТР ФАнең 1 хакыйкый әгъзасы, 2 мөхбир әгъзасы, 10 фән. д-ры һәм 20 фән. кандидаты эшли. Эшләү елларында ТР дәүләт идарәсе органнарына 70 тән артык фәнни-гамәли тәкъдимнәр бирелә; 150 закон проектына, РФ һәм ТР дәүләт программаларына һәм башка норматив документларга экспертиза ясала, 20 монография, 40 томда ел саен чыгарыла торган фәнни хезмәтләр басыла. 1996 дан түбәндәге белгечлекләр буенча аспирантура эшли: икътисад һәм халык хуҗалыгы б-н идарә итү; социаль структура, социаль институтлар һәм процесслар, халыкара һәм Европа хокукы; конституцион һәм муниципаль хокук, социаль философия; укыту һәм тәрбия бирү логикасы һәм теориясе. Институт җитәкчеләре — Ә.З.Гыйльманов, Ф.Г.Хәмидуллин (1995 тән). 2004 нең сентябрендә ябыла.

**СОЦИА́ЛЬ-ИКЪТИСАДИ́ ГЕОГРА́ФИЯ**, җәмгыяви системаларның формалашу һәм үсү закончалыкларын һәм үзенчәлекләрен, ш.у. аларны көйләү, алар б-н идарә итү механизмнарын өйрәнә торган фән; геогр. фәннәре системасының төп бүлекләреннән берсе (гомуми һәм физик география б-н беррәттән). Тармак дисциплиналары (сәнәгать географиясе, агрогеография, транспорт географиясе, мед. географиясе һ.б.ш.) төркемнәренә һәм икътисади (матди җитештерү географиясе һәм җитештерү булмаган сфера географиясе) һәм иҗтимагый (халык һәм аның урнашуы географиясе, сәяси география һ.б.) географияләргә бүленә. С.-и.г. б-н беррәттән формалашалар: терр. иҗтимагый системаларны үстерү фаразларын, гипотеза, концепция, проект һәм программаларын үз эченә алган фаразлау (перспектив) географиясе; терр. иҗтимагый-икътисади системаларның фәза-вакыт буенча төзелешен һәм яшәү закончалыкларын ачыклый торган иҗтимагый-икътисади картография; фәзаи иҗтимагый системаларны үстерүнең теоретик-методологик нигезләнүен тикшерүче матем. география; геогр. мәгълүмат системаларын һәм терр-я мониторингын куллана торган геокибернетика. Терр. системаларны кешеләрнең ялын оештыру урыны буларак үстерү закончалыкларын һәм үзенчәлекләрен өйрәнә торган рекреацион география тиз үсә. С.-и.г.нең кешеләр тормышының фәзаи оешмасын барыннан да элек хезмәт, көнкүреш, ял итү шартлары, шәхесне үстерү һәм халык санын яңадан торгызу ягыннан чыгып өйрәнүче яңа юнәлешләре (яшәү рәвеше географиясе, куллану географиясе, мәдәният географиясе һ.б.) киң үсеш ала бара. Сәяси-терр. берләшмәләрне дәүләтләр (дәүләт төркемнәре) дәрәҗәсендә дә, дәүләтнең үз эчендә дә өйрәнә торган сәяси география яңача үсеш (электораль, үз-үзен тоту, геосәяси) ала.

Татарстанда С.-и.г. 1920–30 елларда формалаша һәм бу Н.-Б.З.*Векслин* тикшеренүләре б-н бәйле (ТАССР халык хуҗалыгын үстерүнең географик факторлары). Соңыннан ул П.В.*Абрамов* (сәнәгать җитештерүен һәм җитештерү көчләрен урнаштыру), Н.И.*Блажко* (терр. җитештерү һәм халыкны урнаштыру системаларында матем.-геогр. модельләштерү), А.М.Трофимов (табигый һәм иҗтимагый-икътисади терр. системалар модельләштерү; геоситуацияләр б-н модельләштерү), Ю.Р.Архипов (геогр. системаларда үзара тәэсир итешү процесслары; халыкны урнаштыруның терр. системаларын модельләштерү), Р.Г.*Хуҗиев* (географиядә континуальлек, дискретлык һәм анык булмаган классификацияләр; терр. һәм тармак мәнфәгатьләрен кабул итү һәм килештерү теориясе); М.В.*Панасюк* (төбәк б-н идарә итүнең геогр. концепциясе; геомәгълүмат системалары); В.А.*Рубцов* (терр. иҗтимагый-икътисади системаларны тотрыклы үстерү концепциясе) хезмәтләрендә үсеш ала. 20 йөз ахыры — 21 йөз башында яңа концептуаль-теоретик юнәлеш — төбәкне үстерүнең, көндәшлеккә сәләтенең, позициясенең иҗтимагый-икътисади аспектлары (В.А.Рубцов, А.М.Трофимов) формалаша. Татарстан икътисад географлары Казанда яшь галимнәрнең 1 нче Бөтенсоюз «Географик системалар: модельләштерү һәм идарә итү проблемалары» конференциясен (1987), СССР Геогр. җәмгыятенең 11 нче съездын (1990), «Хәзерге география һәм әйләнә-тирә мохит» дигән Бөтенроссия конференциясен (1996) оештыруда һәм үткәрүдә актив катнашалар. С.-и.г. буенча белгечләрне Казан ун-тының икътисади геогр. һәм региональ анализ каф. (1937 елда оештырыла) әзерли.

*Әд.:* Архипов Ю.Р. Моделирование территориальных систем расселения. К., 1988; Хузеев Р.Г. Теория принятия компромиссных решений. К., 1988; Трофимов А.М., Игонин Е.И. Концептуальные основы моделирования в географии: Развитие основных путей математизации и формализации в географии. К., 2001; Панасюк М.В. Управление регионом: территориальный подход. К., 2005; Трофимов А.М., Шарыгин М.Д. Общая география: Вопросы теории и методологии. Пермь, 2007.

*В.А.Рубцов.*

**СОЦИОЛИНГВИ́СТИКА** (социаль лингвистика), тел белеменең телнең социаль табигате, иҗтимагый функцияләре, социаль факторларның телгә тәэсир итү механизмнары һәм аның киң җәмәгатьчелек тормышында тоткан урыны б-н бәйле күптөрле мәсьәләләрне өйрәнүче тармагы. С. өчен кызыксыну тудырган объектлар масштабыннан чыгып, макро- һәм микросоциолингвистиканы аерып карыйлар. Беренчесе эре социаль берләшмәләрдә (дәүләт, милләт һ.б.) башкарылучы тел күренешләрен һәм аның б-н бәйле төрле мөнәсәбәтләрне өйрәнә, икенчесе татар телендә сөйләшкән гаилә, аерым коллективлар кебек зур булмаган төркемнәрдә күзәтелүче тел күренешләрен һәм аның б-н бәйле мөнәсәбәтләрне анализлау б-н шөгыльләнә. Татар С.сының нигезе К.Насыйри, Г.Ибраһимов, Г.Сәгъди, Г.Алпаров, Х.Курбатов, В.Хаков һ.б.ның хезмәтләрендә салына. Хәзерге социолингвистик тикшеренүләр үзәгендә татар теленең аның барлык структур баскычларында социаль бүленеше, татарча-русча һәм русча-татарча икетеллелекнең социаль аспектлары, татар теле һәм мәдәният багланышлары, аларның йогынтысы һ.б. тора. Бу юнәлешләр М.Зәкиев, И.Низамов, И.Бәширова һ.б.ның хезмәтләрендә тикшерелә. Тикшеренүләр барышында анкета тутыру, сорашып чыгу, статистик мәгълүматларны өйрәнү һ.б. ысуллар кулланыла.

*Әд.:* Х а к о в В.Х. Тел — тарих көзгесе. К., 2003; Н и з а м о в И.М. Татар социолингвистикасы хәрәкәттә. К., 2011; З а к и е в М.З. Татары: проблема истории и языка. К., 1995; Языковая политика в Республике Татарстан. К., 1998; Язык и этнос на рубеже веков. К., 2002.

*И.М.Низамов.*

**СОЦИОЛО́ГИЯ** (лат. societas — җәмгыять һәм ...*логия*), җәмгыятьнең төрле оешу дәрәҗәсендә (социеталь, институциональ, оешма һәм төркем хәлендә) яшәве һәм үсеше турындагы фән. «С.» атамасы О.Кант тарафыннан «Позитив философия курсы» («Курс позитивной философии», 1830–42) хезмәтендә кертелә. С.дә берничә методологик юнәлеш: җәмгыятькә карата һәркайсының үз карашы булган функциональ (структур-функциональ), конфликт-радикаль, феноменологик, структурализм, постмодернизм һ.б. формалаша. Гомуми социол. концепцияләрдән тыш, аерым социаль ин-тларны тикшерүче теорияләр (икътисади С., шәһәр С.се, гаилә С.се һ.б.) бар.

Россиядә С. буенча беренче хезмәтләр арасында 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Казан галимнәре Н.В.Рейнардт, В.В.*Ивановский*, Г.Ф.*Шершеневич*, Н.В.Первушинның фәнни эшләре була. Казан ун-тында С. курслары 1923 елга кадәр укыла (1923/24 уку елыннан ул буржуаз фән итеп танылa һәм тарихи материализм курсы б-н алмаштырыла). 1920 дә Казанда С. буенча Россиядә беренче тапкыр тарихи материализмның нигезләре бәян ителгән һәм ТАССР Халык мәгарифе комитеты программасына яраклаштырып төзелгән уку ярдәмлеге (С.В.Фарфоровский һәм И.П.Кочергин «Социология»се) чыгарыла. 1920 елларда Казанда Югары уку йортлары каршында иҗтимагый фәннәрне өйрәнү ассоциациясе эшли (С.В.Фарфоровский, М.В.Кочергин, И.С.Кругликов, С.Ушаков һ.б.). 1964 тә Казан ун-тының филос. каф. каршында Н.Г.*Аитов* тарафыннан СССРда беренчеләрдән булып социол. лаб-ясе оештырыла (1993 кә кадәр эшли). Аның хезмәткәрләре халыкның дин тоту (Р.Г.*Балтанов*, 1966–69), хезмәт активлыгы (М.Г.*Нугаев*, 1969–74), девиант тәртипле яшьләр (А.Л.*Салагаев*, 1986–93) проблемаларын тикшерәләр. Лаборатория эшенә ш.у. С.Ә.Әхмәтова, Г.А.Непримерова, В.М.Котельникова зур өлеш кертәләр. Мондый лаб-яләр 1973 тә «Татнефть» ҖБдә (Ю.Е.Дуберман, А.В.Тихонов, А.Н.Юртаев), 1974 тә Казан авиация ин-тында (Г.А.Котельников, Р.В.Волков, И.С.*Рәхмәтуллин*, Л.И.Киселёва), 1975 тә КАМАЗда (Н.С.Фәтхуллин, В.С.Дудченко, А.К.Зайцев, Ю.В.Платонов, А.А.Евсеев) оештырыла. 1970 елларда Казан ун-тының тарих ф-тында «Социологик тикшеренүләр методикасы» (М.Г.Нугаев, С.Ә.Әхмәтова) һәм «Гамәли социология» (А.Л.Салагаев) лекция курслары укыла. Бу елларда респ-када сәнәгать С.се формалаша (М.Г.Нугаев, Г.А.Котельников, А.Н.Юртаев һ.б.). 1991 дә ун-тның тарих ф-тының фәнни коммунизм каф. С. каф. итеп үзгәртелә. 1992 дә Россия социологлары җәмгыятенең Татарстан бүлеге оештырыла (рәисе — ТР ФАнең мөхбир әгъзасы В.В.*Иванов*). 1995–2007 дә Казан ун-тының Мәдәният С.се үзәге тарафыннан (җитәкчесе — С.А.Ерофеев) чит ил фондлары ярдәмендә белем бирүче социол. программалар тормышка ашырыла. ТРда танылган Мәскәү һәм Петербург социологлары җитәкчелегендә хезмәт (О.И.Шкаратан, А.В.Тихонов) һәм этносоциаль (Ю.В.Арутюнян, Л.М.*Дробижева*) мөнәсәбәтләрнең төрле социаль проблемалары тикшерелә. 1993 тән социол. тикшеренүләр ТР ФАнең *Социаль-икътисади һәм хокук фәннәре институты* базасында уздырыла. Татарстанда советтан соңгы чорда респ-кадан читтә танылган 2 социол. мәктәп: этносоциология (Р.Н.*Мусина*, Д.М.*Исхаков*, Т.Г.*Исламшина*, Л.В.Сәгыйтова, Г.Р.*Столярова*, Г.И.Макарова, Л.Р.Низамова һ.б.) һәм девиацияләр С.се (А.Л.Салагаев, Ю.Ю.Комлев, А.В.Шашкин, И.Е.Туриянский, А.Ю.Конов һ.б.) мәктәпләре формалаша. Галимнәрнең тикшеренүләрендә социаль проблемаларның барлык спектрлары диярлек тәкъдим ителә: С. тарихы (Л.Ә.*Борһанова*, В.П.Модестов), мәгариф С.се (Ф.Г.*Зыятдинова*), муниципаль идарә С.се (А.Н.*Ершов*, Ә.З.*Гыйльманов*), шәхес С.се (Ю.Р.Хәйруллина), гаилә С. (Л.В.*Карцева*, Ф.Ә.*Илдарханова*), социаль проблемалар С.се (И.Г.Ясәвиев), идеология С.се (А.Р.Тузиков) һ.б.

*Әд.:* З и я т д и н о в а Ф.Г. Социальное положение и престиж учительства: проблемы, пути решения. М., 1992; И с л а м ш и н а Т.Г. Этнические ценности полиэтничного общества. К., 1996; Т и т о в а Т.А. Этническое самосознание в национально-смешанных семьях. К., 1999; М у с и н а Р.Н. Этносоциальное развитие и идентичность современных татар // Татары. К., 2001; И л ь д а р х а н о в а Ф.А. Семья и личность: Опыт социально-педагогического анализа. К., 2002; С т о л я р о в а Г.Р. Феномен межэтнического взаимодействия: Опыт постсоветского Татарстана. К., 2004; Я с а в е е в И.Г. Конструирование социальных проблем средствами массовой коммуникации. К., 2004.

*А.Л.Салагаев.*

**СОШЕ́СТВЕНСКИЙ** Николай Александрович (26.9.1876, Саратов өлкәсенең Ексара а., хәзер Вязовка а. — 18.1.1941, Мәскәү), вет. фармакологы һәм токсикологы, вет. фән. д-ры (1934), проф. (1916), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1930). Вет. фармакологларының Казан һәм Россия фәнни мәктәпләрен нигезләүчеләрнең берсе. Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1906), Казан губернасының Кузнецкий өязендә өяз вет. табибе булып эшли. 1907–21 елларда Казан вет. ин-тында: патологик анатомия каф. прозекторы, приват-доцент (1911–16), фармакол. каф. мөдире (1916 дан). 1921 дән Мәскәү вет. ин-тының фармакол. каф. мөдире, 1924–40 та Дәүләт эксперименталь вет. ин-тының фармакол. каф. мөдире, 1924–40 та Эшче-Крәстиян Кызыл Армиясенең (РККА) Хәрби-вет. химик лаб-ясе башлыгы, бер үк вакытта Эксперименталь эндокринология ин-тының фармакол. каф. мөдире, 1937–40 та РККА Хәрби-вет. академиясенең токсикология каф. башлыгы. 1940–41 дә Мәскәү зоовет. ин-тының фармакол. каф. мөдире. Фәнни эзләнүләре төрле нейротроп дару матдәләренең ашказаны-эчәк трактына (секрет бүлеп чыгару һәм хәрәкәт эшчәнлеге функцияләренә), йөрәк мускулына һәм кан тамырларына фармакологик тәэсирен өйрәнү өлкәсенә; атның сулыш алуын саклауның физиол. нигезләрен һәм терлекләргә агу матдәләреннән зыян күргән очракта беренче ярдәм күрсәтү, патогенетик терапия ысулларын эшләүгә карый. С. тарафыннан атлар өчен противогаз конструкциясе эшләнә. Югары уку йортлары өчен гистология, патофизиол., токсикология буенча 6 фундаменталь дәреслек, 70 тән артык монография авторы. Кызыл Йолдыз ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Патология и терапия отравлений животных боевыми отравляющими веществами. М., 1928; Токсикология боевых отравляющих веществ. М.–Л., 1933; Курс фармакологии и фармотерапии. М., 1937.

*Әд.:* Н а б и е в Ф.Г. Профессор Николай Александрович Сошественский. К., 2001; Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*Ф.Г.Нәбиев.*

**«СО́ШНИКИ»**, атналык газета. 1906 елның декабреннән 1907 нең гыйнварына кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә. Баштагы (1 һәм 2 нче саннар) нашире «Патша-рус халкы җәмгыяте» («Царско-народное русское общество») һәм «*Рус халкы берлеге*»*нең* Казан бүлеге рәисе В.Ф.*Залесский* була, мөхәррире — «Рус җыены»ның («Русское собрание») Казан бүлеге әгъзасы П.К.Кувшинов; 3 нче саннан Залесский ике вазифаны да башкара. «Крәстияннәргә» багышлана (шул ук кешеләр тарафыннан чыгарылган «шәһәр кешеләренә» аталган «*Черносотенец*» г-тасы б-н бер үк вакытта дөнья күрә). Консерватив-карагруһ юнәлеш тота, Казан уң монархик оешмаларының аграр (община-хутор җирбиләүчелеге), милли (нигездә, европа-

ча) һ.б. мәсьәләләргә карашларын пропагандалый. Материалларның күп өлеше Залесский каләменә туры килә. Газетада редакциянең 2 нче Дәүләт Думасына сайлауда кандидатларын күрсәтергә каргуһ оешмалар вәкилләре өчен тавыш бирүгә чакырган язмалары, агитация-пропаганда материаллары һәм чыгышлар, монархик әчтәлектәге шигырь һәм гимннар, халык тормышыннан кыска мәкаләләр басыла. Аеруча мөһим мәкаләләр: И.Л.Панфиловның «Крәстиян мәсьәләсен чишүдә аеруча дөрес юл буларак община-хутор җирбиләүчелеге» («Общинно-хуторское землевладение как наиболее правильный путь разрешения крестьянского вопроса»), Залесскийның «Сәяси партияләр» («Политические партии») язмалары; Киевтагы «рус кешеләренең» 3 нче Бөтенроссия съезды турындагы хисабы. Газета арзанлы һәм бөтен кеше сатып алырлык булсын дип уйланыла, әмма 1906 ның 13 декабреннән аның бәясе ун тапкырга арта, бу исә газета чыгуның тукталуына китерә.

*Әд.:* Алексеев И.Е. Русское национальное движение в Казанской губернии и Татарстане: конец XIX — начало XX веков. К., 2004.

*И.Е.Алексеев.*

**СО́ШНИКОВ** Валерий Александрович (20.1.1962, Казан), химик-технолог, техн. фән. д-ры (2007). 1985 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый һәм шунда ук эшли башлый. 1998 дән «Татспиртпром» АҖдә, 2000–03 тә «Сәнәгать технологияләре» АҖ директоры. 2003 тән Казан технол. ун-тында. Хезмәтләре биотехнологияләр өлкәсенә карый. Аның фәнни эшләнмәләре ТР, РФ һәм якын чит илләр предприятиеләрендә производствога кертелә. Уйлап табуга 19 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Способы регулирования химических и сенсорных характеристик спирта // Производство спирта и ликёроводочных изделий. 2005. № 2 (автордаш); Лимитирующий фактор низкотемпературного разваривания крахмалистого сырья // Производство спирта и ликёроводочных изделий. 2005. № 5 (автордаш); Интенсификация спиртового брожения комплексонами // Производство спирта и ликёроводочных изделий. 2006. № 1.

**«СОЮ́З»**, Казан тәҗрибә конструкторлык бюросы (КТКБ), 1953 елда 16 нчы Казан моторлар төзү з-ды (хәзер *Казан моторлар төзү берләшмәсе*) каршындагы тәҗрибә КБсы буларак оештырыла. 1957 дән мөстәкыйль КБ-16, 1967 дән Моторлар төзү проектлар бюросы, 1978 дән «С.» Казан моторлар төзү з-ды, 1990 нан КТКБ «Союз», 2001 дән АҖ, 2002 дән «Алмаз-Антей» ҖБ концерны составында. 1950 елларның 1 нче яртысында тәҗрибә КБ Ту-16 бомбардировщигы өчен АМ-3 турбореактив двигателен серияләп җитештерүнең техник өлешен тәэмин итә; дөньяда беренче реактив пассажир самолёты Ту-104 һәм Ту-16, М-4, МС бомбардировщиклары өчен РД-3М турбореактив двигателен һәм аның РД-3М-500 модификациясен эшли. 1955–65 тә тәҗрибә КБда зур ераклыкларга оча торган бомбардировщиклар һәм пассажир лайнерлары өчен күп төрле турбореактив двигатель проектлары эшләнә; пассажир һәм транспорт самолётлары Ил-18, ш.у. барлык типтагы Ан самолётларының двигательләрен автомат кабызу һәм бортның электр челтәрен туендыру өчен турбореактив ТГ-16 җайланмасы конструкцияләнә һәм җитештерүгә кертелә (хәзер дә кулланыла); Ил-62 самолёты өчен НК-8 турбореактив двигателе эшләнеп бетә һәм серияләп җитештерүгә кертелә. 1959 да КБда җир өсте, һава һәм диңгездән җибәрелә торган ракеталар өчен каты ягулыклы двигательләр төзүгә әзерлек эшләре башлана, 1966 дан эшчәнлек тулысы б-н шушы тематикага күчерелә. Пр-тиедә төрле класстагы ракеталар, ш.и. илнең ул вакыттагы һава көчләреннән саклану системасының нигезен тәшкил итүче «С-300В» һәм «Бук» комплекслары өчен 11 исемдәге югары нәтиҗәле двигатель эшләнә (кораллануга кабул ителәләр); кораллануда гамәлдә йөрүче ракета двигательләренең хезмәт срогын арттыру чаралары күрелә.

1980 еллар башыннан конверсия эшчәнлеге юнәлеше кысаларында 20 *кВт* ка кадәр егәрлекле технологик $CO_2$-лазерлар (И.В.Курчатов исем. Атом энергиясе ин-тының Троицк ф-лы б-н берлектә), металларны эретеп ябыштыру, кисү һәм ныгыту өчен лазерлы технологик комплекслар эшләнә. 1990 елларда «ЗИЛ», «ГАЗ», «КАМАЗ», «МАЗ» автомобильләренә югары басымлы кысылган метан урнаштыру өчен 400 *л* га кадәр сыешлыклы композицион (пыяла-пластик) баллоннар («Газпром» АҖнең автомобиль транспортын газ ягулыгына күчерү буенча максатчан программасы кысаларында); 5000 $м^3$ га кадәр газ сыйдырышлы күчмә газ заправкалары; шикәр чөгендерен, кукуруз, көнбагыш, сояны төгәл чәчү чәчкечләре; шикәр чөгендерен казу һәм өемнәргә салу җайланмалары; кәбестә һ.б. культураларның үсентеләрен ачык грунтка күчереп утырту машиналары проектлана һәм серияләп җитештерүгә кертелә (РФнең күп төбәкләрендә кулланылалар).

«С.» дәүләтнең милли куркынычсызлыгын тәэмин итүдә стратегик әһәмияткә ия булган федераль пр-тиеләр исемлегенә кертелгән; пр-тиедә продукциянең сыйфаты б-н ГОСТ Р ИСО 9001–2001 (2002) таләпләренә туры килә торган идарә системасы эшли. «С.» югары фәнни оборона заказларын һәм конверсия эшләрен үти алырлык матди-техник һәм тәҗрибә базасына ия. Пр-тиенең 3 хезмәткәре — техник фән. д-ры, 42 хезмәткәр — техник һәм физика-матем. фән. канд.; хезмәткәрләр тарафыннан 500 дән артык уйлап табу таныклыгы һәм патент алынган. 250 дән күбрәк кеше хөкүмәт бүләкләренә лаек була, ш.и. 2 кеше — Ленин премиясе, 6 кеше — СССР, РФ Дәүләт, 1 кеше — СССР МС, 2 кеше — Ленин комсомолы бүләкләренә ия; 4 кеше — РСФСР, ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе, 7 кеше — РФ, ТАССРның атказ. машина төзүчесе, 7 кеше — РФнең атказ. конструкторы, 2 кеше РФнең атказ. химигы исемен йөртә.

Пр-тиенең җитәкчеләре: П.Ф.*Зубец* (1953–83), И.Х.*Фәхретдинов* (1983–95), Р.Х.Рәимов (1996–2008), Н.Ш.Латыйпов (2008 дән).

*Әд.:* Первов М.А. Системы ракетно-космической обороны России создавались так. М., 2003.

*А.Я.Семичёв.*

**«СОЮЗПЕЧА́ТЬ»**, СССР Элемтә министрлыгының массакүләм ихтыяҗга ия вакытлы матбугат һәм басмалар тарату оешмасы. Респ-када Матбугат тарату үзәк идарәсе буларак 1932 елда оештырыла. 1950 елларда вакытлы матбугат басмаларына язылу һәм аларны ваклап сату б-н шөгыльләнүче «С.» респ-ка агентлыгы итеп үзгәртелә. Басмаларның исемлеге һәм аларга язылу шартлары «С.» баш идарәсе һәм «С.» респ-ка агентлыгы тарафыннан ел саен чыгарылган каталогларда һәм прейскурантларда күрсәтелә. Вакытлы матбугатка еллык язылу күләме 4,5 млн. данәдән арта. «С.»нең респ-каның һәр районында бүлекчәләре һәм тармакланган ваклап сату челтәре (3 махсус кибет, респ-ка күмәртәләп сату базасы, 1200 кеше эшләгән 200 дән артык киоск), күчмә сәүдә чаралары, газеталар һәм журналлар сату буенча автоматлары була. «С.» ваклап сату челтәре аша, вакытлы матбугат басмалары б-н бергә, филателия эшләнмәләре, китаплар, брошюралар, сынлы сәнгать продукциясе, значоклар һ.б. массакүләм ихтыяҗга ия товарлар сатыла. 1989 да товар әйләнеше 11 млн. сум тәшкил итә. 1990 да, вакытлы матбугатка язылу вазифасы ТАССРның Элемтә җитештерү-техник идарәсенә тапшырылып, гамәлдән чыгарыла. «С.»нең район бүлекчәләре район элемтә үзәкләре составына кертелә. «С.»нең Казандагы һәм Чаллыдагы элекке бүлекчәләре вакытлы матбугат басмаларын һ.б. вак күмәртә продукциясен ваклап сатучы мөстәкыйль пр-тиеләр булараk эшлиләр.

*Г.Я.Мәүлетова, Л.И.Овчинников.*

**СО́Я** (Glicine), кузаклылар семьялыгыннан үләнчел үсемлекләр ыругы; азык, техник, терлек азыгы һәм сидераль культура. 10 төре Африка һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиянең дымлы тропиклары һәм субтропикларында үсә. Россиядә С.ның 1 кыргый төре (G.hispiola, яисә, G.max, Уссурий С.сыннан килеп чыккан) культуралаштырылган (Ерак Көнчыгышта), 19 йөз ахырыннан бөтен җирдә үстерелә. Берьеллык үсемлекнең 4 астөре бар: Корея С.сы, Маньчжурия С.сы (аңа РФдә үстерелә торган барлык төрләр керә), Кытай С.сы һәм Һиндстан С.сы. Куагы туры, 0,2–2 *м* биеклектә (үсемлеге һәм кузаклары каты кыллар б-н капланган), төп тамыр системалы. Яфраклары 3–5 яфракчыктан, чәчәк оешмасы 2–25 үз-үзеннән серкәләнүче чәчәкләрдән тора. Җимеше — кузак, сызыклы яисә кылычсыман, төсе ачык һәм кара, 2–3 (сирәгрәк 1 яисә 4) аксыл орлыклары бар (өлгергәндә ярылмыйлар). 1000 орлыкның авырлыгы 60 тан 425 *г* га кадәр. Яктылык һәм дым ярата. Кара туфракта яхшы үсә, ачы, сазлыклы, тозлы туфракны яратмый. С.дан азык продуктлары (бөртекле ашлык, он, май, маргарин, сөт һәм эремчек, кондитер әйберләре), ясалма сүс, пластмасса, җилем, лак, буяулар, сабын, терлек азыгы (яшел масса, печән, түп, шрот) әзерләнә. ТРда С. чәчүлеклә-

ре 3 мең *га* били (2008), «СибНИИК-315» сорты үстерелә.

*Әд.:* Бадина Г.В., Королёв А.В., Королёва Р.О. Основы агрономии. Л., 1988.

**СӨБХАНКУ́ЛОВ** Мөгаллим Әкрам улы (11.4.1920, БАССРның хәзерге Бакалы р-ны Иске Корыч а. — 10.9.1976, Дүшәнбе ш.), математик, физика-матем. фән. д-ры (1963), проф. (1964). 1947 елда Ташкент ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1954 тән Таҗик ун-тында, физика-матем. ф-ты деканы, функцияләр теориясе һәм матем. анализ каф. мөдире. Хезмәтләре таубер теоремаларына һәм аларны куллануга карый. С. иярешле Фурье рәтләренең, кабатлы тригонометрик рәтләрнең һәм башка бик күп функцияләрнең аларга кабатлы иярешле рәтләренең җыелучанлыгы һәм кушылучанлыгы тизлеген тикшерү өчен Фату тибындагы теоремалар куллану буенча нәтиҗәләр ала. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Комплексные тауберовы теоремы типа теоремы Келдыша с остатком // Докл. АН СССР. 1972. Т. 202, № 4 (автордаш); Тауберовы теоремы с остатком. М., 1976; Приближение неполных сопряжённых функций частными суммами сопряжённых рядов и сингулярными интегралами // Докл. АН Тадж. ССР. 1976. Т. 19, № 3.

**СӨБХАНКУ́ЛОВ** Таһир Йомадил улы (15.11.1954, БАССРның Чишмә р-ны Ярми а.), скульптор. В.И.Ленин исем. Мәскәү пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тын тәмамлый (1977). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1984). Мәскәүдә «Кояшлы квадрат» халыкара рәссамнар оешмасы (1997), «Рәссам» татар-башкорт рәссамнарының Мәскәүдәге иҗат берлеге (2000) әгъзасы. Мәскәүдә яши. Заманча скульптураның сыгылмалы телен сәнгатьле үстерүдә әйдәп баручы рәссамнарның берсе. С.ның стилистик эзләнүләре 19 йөз ахыры — 20 йөз башындагы Европа йогынтысы традицияләренә (А.Майоль), 20 йөзнең 1 нче чиреге — 20 йөз уртасы скульптор-модернистларының тәҗрибәләренә (К.Бранкузи, Д.Смит) таяна. Композицияле һәм монументаль-декоратив скульптура жанрларында эшли, әсәрләрен мәрмәрдә, бронза, тоныкландырылган җиз, шамот, агачта башкара. Хатын-кыз гүзәллеге һәм мәхәббәт темасы — С. иҗатында иң төп юнәлешләрнең берсе: «Торс» (1981), «Көзге белән» (1982), «Яз» (1987), «Утырып торучы ялангач кыз» (1990). «Казан Венерасы» (1997), «Яңгыр» (1999). Ана һәм бала темасы «Тынычлану» (1984), «Исәнме, эти!» (1990), «Ана һәм бала» (1992), «Әни белән» (1995) әсәрләрендә чагылдырыла. С.ның абстракт скульптурасы, башлыча, табигый материаллардан башкарылган (буялган агач, таш) һәм биоморф күләмнәрдә сурәтләнгән: «Спираль» (1990), «Ак чиксезлек» (1991), «Чәчәк» (1994), «Төштә икәүләп» (2002), «Гаилә» (2008) һ.б. Монументаль-декоратив сыннар авторы: «Абстракт композиция» (1991, таш; Уфада); «Су анасы» фонтаны (1997, бронза, Казанда); сыннар: «Мәхәббәт» (1995, агач), «Гаилә» (2000, агач), «Ана һәм бала» (2007, таш; барысы да Мәскәүдәге «Музеон» сәнгать паркында), «Сирин кошы» (1999, Мәскәүдәге К.А.Васильев музее терр-ясендә), «Таш чәчәк» (2001, таш; Оденслунда ш. Швеция).



Т.Й.Сөбханкулов. «Инеш буенда». Бронза. 2005.

Күргәзмәләрдә, ш.и. «Сын квадриенналесы» (Рига, 1985), «Илнең яшьлегe» (Мәскәү, 1990), «Татарт» бөтентатар (С.-Петербург–Казан, 1991), «Аванпост» (Мәскәү, 1993), «Вариант-93» (Мәскәү, 1993) күргәзмәләрендә, «Фәза һәм шәкел» бөтенроссия сыннар күргәзмәләрендә (Рязань ш., 1994; Уфа ш., 2007), «Кояшлы квадрат» иҗат берлеге күргәзмәләрендә (Мәскәү, 1996, 1999, 2005), «Арт-Манеж» (Мәскәү, 1997, 2007, 2008), Мәскәү халыкара сәнгать салоны (1998, 2000, 2008), «Яңа дәвер — сәнгатьтә яңалык» (Мәскәү, 2001), «Рәссам» иҗат берлеге рәссамнарының (Мәскәү, 2003, 2004, 2006) күргәзмәләрендә, «Arsima» галереясындагы күргәзмәсендә (Париж, 2005–06), «Графика һәм скульптура»; «Башка чынбарлык», «Россия Рәссамнар берлеге Мәскәү оешмасына 50 ел» (барысы да — Мәскәү, 2008) күргәзмәләрендә, РФ Рәссамнар берлегенең бөтенроссия сәнгать күргәзмәсендә (Мәскәү, 2009); күп кенә бөтенроссия һәм халыкара скульптура симпозиумнарында — «Музеон» сәнгать паркы» (Мәскәү, 1995, 2000, 2002), «Skulpturpark» (Оденслунда ш., Швеция, 2001) һ.б.да катнаша.

Шәхси күргәзмәләре Мәскәүдә (1991, 2000), Казанда (1997), Люксембургта (1999), Оденслундада (2001), Подольскида (2004), Лобненскида (2009), Рязаньда (2012) уздырыла.

Әсәрләре Дәүләт Третьяков галереясында (Мәскәү), «Казан» милли мәдәният үзәгендә, И.П.Пожалостин исем. Рязань өлкә сәнгать музеенда, М.В.Нестеров исем. Башкорт сәнгать музеенда, Бөекбритания, Германия, Испания, Канада, АКШ, Финляндия. Швейцария, Швециядәге шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Из дерева и бронзы // Рампа. 1997. № 8.

*Г.Р.Фәйзрахманова.*

**СӨБХАНКУ́ЛОВЛАР**, татар морзалары нәселе. Оренбург губернасының Уфа өязе Салих һәм Ярми авылларында яшәгәннәр. С.ны Оренбург губернасының морзалар китабына кертү 1825 елда билгеләнә. Нәсел башлыгы — мишәрләр старшинасы Сәетбаттал Сөбханкулов (1798 дән поручик); 19 йөз уртасында аның уллары Мөхәммәдвәли, Әхмәтвәли, оныклары Әбелгани, Әхмәтша, Шаһиәхмәт, Шаһимөхәммәд, Ризван да морзалар китапларында исәптә тора.

*Әд.:* Новиков В.А. Сборник материалов для истории уфимского дворянства. Уфа, 1879; Габдуллин И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

**СӨБХИ́** (Subhi), Мостафа (1882, Гиресун ш., Төркия — 28.1.1921, Трабзон ш. янында, шунда ук), төрек сәясәт эшлеклесе. Истанбул ун-тын тәмамлый (1906), аннан соң Сорбоннада укый. 1908 елдагы яшь төрекләр рев-циясеннән соң Төркиягә кире кайта. Истанбулның югары уку йортларында укыта, проф. Госманлылар соц. партиясе әгъзасы (1910). Битләрендә хөкүмәт сәясәте тәнкыйтьләнгән «Ифһам» («Белдерү») г-тасы мөхәррире. 1913 тә кулга алына, 1914 тә сөргеннән Россиягә кача. Беренче бөтендөнья сугышы башында ирегеннән мәхрүм ителә, аннан соң Калуга шәһәренә, 1915 тә — Уральск шәһәренә сөргенгә җибәрелә. Окт. рев-циясеннән соң Мәскәүгә килә, Үзәк мөселман комис-ты җитәкчеләре — М.М.*Вахитов*, Ш.Ә.*Манатов*, Г.Г.*Ибраһимов* б-н элемтәләр урнаштыра. Тарихчы Н.Г.Субаев әйтүенчә, нәкъ менә М.М.Вахитов һәм Г.Г.Ибраһимов «Совет Россиясендә аның революцион укытучыларына әвереләләр». С. төрек телендә «Yeni dünya» («Яңа дөнья») г-тасы нәшер итә. 1918 нең июнендә социалист-мөселманнарның ниятләнгән съезды б-н бәйле рәвештә Казанга килә. Петцольд з-дында төрек хәрби тоткыннары алдында чыгыш ясый; төрек социалистларының Мәскәүдә булачак конференциясе мәсьәләсе буенча киңәшмә уздыра. Конференциягә Казаннан да делегатлар сайлана. Казанны Чех-словак корпусы частьларыннан һәм КОМУЧның Халык армиясеннән азат иткәннән соң, Идел буе, Урал буе һәм Себер мөселман революцион оешмаларын яңадан булдыру комиссиясе составына керә. Төрек социалистларының Казан бүлекчәсен оештыруда катнаша, Кызыл Армиянең төрек ротасы комиссары булып сайлана. 1919 ның гыйнварында Казанда 1 нче тюркологлар конференциясен оештыруда һәм аның эшендә катнаша. Анда татар теле орфографиясе һәм дөрес язу мәсьәләләре карала (С. гарәп имлясыннан латин графикасына күчүне тәкъдим итә). Коминтернның беренче конгрессында (1919), Шәрекъ халыкларының беренче корылтаенда (1920) катнаша. Төркия коммунистлар партиясенең Бакуда узган 1 нче съездын оештыручыларның берсе (1920); съездда партиянең рәисе итеп сайлана. Төркиягә кайтканда С. һәм башка төрек коммунистлары төркеме жандармнар тарафыннан тотып алына һәм диңгезгә чыгарып үтерелә.

*Әд.:* Субаев Н.А. Субхи Мустафа // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

**СӨЕМБИКӘ́** (Сөенбикә) (?-1554 елдан соң, Касыйм ш.), Казан ханлыгы идарәчесе (1549–51). Нугай бәге Йосыф кызы, Казан ханы *Җангалинең* хатыны. Җангалигә 1533 тә кияүгә бирелә. Аның үлеменнән соң (1535), Сафагәрәй хан хатыны. 1549 да Сафагәрәй,

идарәчелекне улы *Үтәмешгәрәй ханга* калдырып, кинәт үлеп китә; С. балигъ булмаган улы Үтәмешгәрәй ханның регенты вазифасын ала. Ханлык б-н *Кошчак бәккә* таянып идарә итә; Кырымга йөз тоткан сәясәт алып барырга омтылуы б-н Казан аксөякләрендә дә, рус хөкүмәтендә дә канәгатьсезлек тудыра. Рус дәүләте б-н хәрби каршылыкта тору (к. *Казанга рус дәүләте яулары*) һәм аксөякләр арасында үзара килешү булмау сәбәпле, С. хөкүмәте Мәскәү яклы Казан аксөякләре тарафыннан бәреп төшерелә. С. улын алып атасы тарафына, Нугай Урдасына качарга омтылыш ясый, әмма тотыла. Казанның яңа хөкүмәте һәм рус дәүләте арасында төзелгән килешү шартлары нигезендә С. һәм аның улы 1551 нең 11 августында Мәскәүгә озатылалар. Соңрак ул Шаһгалигә кияүгә бирелә һәм Касыйм шәһәренә җибәрелә. Үтәмешгәрәй Александр исеме б-н чукындырыла (1553). Кайбер мәгълүматларга караганда, Шаһгали С.гә карата үтә кешелексез мөнәсәбәттә була. Йосыф бәкнең патша Иван IV кә хатлар язып, кызын үзе янына кайтарырга тырышуы нәтиҗә бирми. 1554 елда Йосыф бәк фаҗигале төстә һәлак булганнан соң, С. исеменең сәяси һәм дипломатик әһәмияте юкка чыга.



«Сөембикә ханбикә улы белән». Рәссам П.Дементьев.

С. — дөнья тарихындагы мөселман идарәче хатын-кызларының иң беренчеләреннән санала. Татар халкының тарихи хәтерендә С. ханбикәнең язмышы Казан ханлыгы фаҗигасе б-н символик рәвештә бәйләнгән; аны тоткын итү һәм Мәскәүгә озату Казанның руслар тарафыннан яулануы, татарларның үз дәүләтләрен югалтулары б-н тәңгәлләштерелә. С.нең шәхесе, аның фаҗигале язмышы халык дастанында («Сөембикә бәете»), рус, татар, төрек язучылары һәм публицистлары иҗатында чагылыш таба. Ханбикәгә багышланган иң беренче тарихи-публицистик хезмәт — С.нең романтик образы (сәяси мәнфәгатьләргә түгел, ә мәхәббәт, нәфрәт, көнчелек хисләренә буйсынып эш иткән зирәк, чибәр, әмма мәкерле хатын-кыз) тасвирланган «*Казанский летописец*» («Казан елъязмачысы», 16 йөзнең 2 нче яртысы) әсәре. Мондый чи-



«Тотык ителгән Сөембикә ханбикәнең Казаннан китүе». Рәссам В.Г.Худяков. 1896.

шелеш соңрак иҗат ителгән әсәрләргә дә йогынты ясый. 18 йөз — 19 йөз башы рус тарихи поэмаларында — М.М.Херасков, «Россия́да» (1779), А.Н.Грузинцев, «Буйсындырылган Казан» («Покорённая Казань», 1810), Г.Р.Державин, «Грозный, яки Казанны буйсындыру» («Грозный, или Покорение Казани», 1814) — С. Казан символы рәвешендә, русларга каршы юнәлдерелгән «кара» көчләрнең үзәге, мәкерле, аяусыз, шул ук вакытта рәхимле итеп сурәтләнә. 19 йөз башыннан рус тарихи драма һәм романнарында С. образы үзгәреш кичерә башлый, ул сәяси мәнфәгатьләрне шәхси хисләре хакына корбан иткән шәрекъ хатын-кызы сыйфатындагы романтик натура буларак тасвирлана — С.Н.Глинка, «Сөембикә, яки Казан ханлыгының буйсындырылуы» («Сумбека, или падение Казанского царства», 1806), М.С.Рыбушкин, «Иоанн, яки Казанны алу» («Иоанн, или Взятие Казани», 1814). Соңрак, В.И.Лапинның «Казанны алу» («Взятие Казани», 1855) әсәрендә С. образын чынбарлыкка якынлаштырып, катлаулы һәм фаҗигале итеп күзаллау омтылышы ясала. Татар тарих белемендә (Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, Һ.Атласи һ.б.), романнар, шигъри әсәрләр, тарихи драмаларда (Г.Исхакый, М.Гафури, Ф.Әмирхан, Ф.Туйкин һ.б.) С. милли азатлык һәм рус баскынчылыгына каршы көрәш символы буларак сынландырыла. Казан ханлыгы яуланыр алдыннан ул кичергән фаҗига халыкта азатлык өчен көрәшне дәвам итү ниятен көчәйтә. Татар әдипләренең романтик рухтагы әсәрләрендә (Ф.Әмирхан, Ш.Әхмәдиев һ.б.) татар ханбикәсенең идеаллаштырылган образы тудырыла. Татар халкының һәм С.нең уртак язмышы турында уйланып, Ф.Әмирхан ханбикәне «милләт анасы», «халык кызы» дип атый. Татар әдәбияты аша С. образы төрек авторлары (И.В.Нәүрүзхан, Л.Каран, М.Кайа һ.б.) әсәрләренә үтеп керә һәм татар халкының милли сыйфатлары чагылышына әверелә. 1990 елларда иҗат ителгән татар тарихи прозасында — Р.Батулланың «Сөембикә» (1992), М.Хәбибуллинның «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» (1992) романнарында һәм башка әсәрләрдә С. образында татар халкының баш имәс хөр рухы һәм ирек сөю сыйфатлары туплап бирелә. С. исеме шәһәр топонимикасында (Казанда Сөембикә манарасы, Чаллыда Сөембикә проспекты һ.б.), вакытлы матбугатта («Сөембикә» ж-лы) мәңгеләштерелгән, Кече планеталарның берсенә С. исеме бирелгән.

Чыг.: Катанов Н.Ф. Исторические песни Казанских татар // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1899. Т. 15, вып. 3; Казанская история. М.–Л., 1954; Посольские книги по связям России с Ногайской Ордой. 1551–1561 гг. К., 2006.

*Әд.:* Г а з и з Г. Татар тарихы. К., 1922; А т л а с и Һ. Себер тарихы. Сөенбикә. Казан ханлыгы. К., 1993; У р м а н ч е Ф. Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә. К., 1997; ш у л у к. Сөембикә ханбикә: Җыентык. К., 2001; Б а ж е н о в Н.К. Казанская история. К., 1847; В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1863–64. Ч. 1–2; Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Т р е п а в л о в В.В. История Ногайской Орды. М., 2002; И с х а к о в Д.М., И з м а й л о в И.Л. Введение в историю Казанского ханства. К., 2005.

*И.Л.Измайлов.*

**СӨЕМБИКӘ́**, кече планета (№ 27–849), 1994 елның 29 октябрендә Казан ун-тының *Төньяк Кавказ астрономия станциясендә* һәвәскәр астроном Т.Крячко тарафыннан ачыла һәм татар ханбикәсе *Сөембикә* исеме б-н атала. С.нең Кояштан ераклыгы 1,8 а.б.нән 2,7 а.б.нә кадәр үзгәрә. Кояш тирәли әйләнү периоды 3,4 ел. Планетаның диаметры 4 *км*.

**«СӨЕМБИКӘ́»**, хатын-кызлар өчен рәсемле журнал. 1913 елның 27 октябреннән 1918 нең 8 гыйнварына кадәр Казанда татар телендә аена 2 тапкыр нәшер ителә, барысы 115 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — Я.*Хәлили*. «*Өмид*» һәм «*Мәгариф*» нәшриятларында басыла. Актив авторлары арасында — М.Акчурина, Ф.Борнаш, Л.Гадел, Н.Думави, Р.Ибраһимия, М.Мозаффария, Ф.Сөләймания һ.б. Журнал үзенең максаты итеп хатын-кызларны татар милли йолалары нигезендә тәрбияләүне куя. Анда Россия һәм анан читтә хатын-кызларның урыны һәм роле турындагы материаллар басыла, әхлак мәсьәләләре, бала тәрбияләү проблемалары



«Сөембикә» журналы.

турында фикер алышына, йорт эшләре буенча киңәшләр бирелә. Даими сәхифәләре: «Хатыннар хокукы», «Балаларны тәрбияләү», «Мөселман хатын-кызлары хәрәкәте», «Өй хуҗалыгы», «Кулинария». Җирле органнар тарафыннан совет хөкүмәтенең боль-

шевистик булмаган барлык матбугат органнарын нәшер итүне туктату турындагы декреты нигезендә ябыла.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Латыйпова Р. «Сөембикә» журналы // Йөз еллык матбугатыбыз: үткәне, бүгенгесе, киләчәге: фәнни-гамәли конференция материаллары. К., 2005.

**«СӨЕМБИКӘ́»**, хатын-кызлар өчен иҗтимагый-сәяси, әдәби-нәфис рәсемле айлык журнал. Казанда татар телендә нәшер ителә. 1926 елның августыннан «Азат хатын» исеме б-н чыга, нашире — ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты. 1941–57 дә басылмый, 1958 дә кабат торгызыла, 1991 дән хәзерге исеме б-н чыга башлый. Оештыручысы — «Татмедиа» ААҖ. Төрле еллардагы баш мөхәррирләре — Г.Гафурова, Ш.Кәримова, Ш.Азанова, Р.Әхмәтшина, А.Ф.Хәсәнова, В.Ф.Ихсанова, Р.Р.Туфитуллова, Ф.Р.Бәдретдинова, Л.Р.Юнысова. Башлангыч чорында Һ.Такташ журналның җаваплы сәркатибе була, төрле елларда язучылар: Д.Зөбәерова, К.Тимбикова, М.Маликова, Г.Шәрәфетдинов, М.Әмирханов, С.Ибраһимова һ.б.; рәссамнар И.Әхмәдиев, Х.Әхмәтҗанов, М.Мөхәммәтҗанов, А.Үтәгәнов, Т.Хаҗиәхмәтов, С.Ибрагимова, А.Тимергалина һ.б.; фотохәбәрчеләр: М.Блатт, Д.Бунтуков, Ф.Гобәев, Г.Хафизов, Р.Якупов һ.б. эшли. Журнал б-н күренекле язучылар Г.Бәширов, Ә.Еники, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиев, Т.Миңнуллин, Х.Сарьян, С.Сөләйманова һ.б. хезмәттәшлек итә. Нигез салынганнан бирле журналда хатын-кызларның иҗтимагый һәм хезмәт эшчәнлегенә багышланган мәкаләләр, гаилә-көнкүреш темасына очерклар, хикәяләр, лирик шигырьләр, поэмалар басыла; театр, рәсем һәм музыка сәнгате үсеше мәсьәләләре яктыртыла, хуҗалык алып бару һәм сәламәт яшәү буенча киңәшләр бирелә. Журнал бик тиз популярлаша, 1930 елларга аның тиражы 15 мең данәгә җитә. 1937 дә мөхәррире Г.Гафурова репрессияләнә: журнал күбрәк партия документларын, иҗтимагый-сәяси материалларны чыгара. 1958 дә кабат торгызылгач, басма баштагы тематик юнәлешен саклый, укучыларны Бөек Ватан сугышында катнашкан хатын-кызлар, тыл хезмәтчәннәре б-н таныштыра; өлгеләр һәм тегү буенча күрсәтмәләр б-н тәэмин ителгән модалы кием модельләренең график рәсемнәре (1970 тән — фотосурәтләр), косметика, аксессуарлар куллану буенча тәкъдимнәр, этикет кагыйдәләре басыла. Журнал татар телендә мода турындагы төп мәгълүмат чыганагы булып тора, укучыларда яхшы зәвык тәрбияли. 1970 елларда татар басмалары арасында рекордлы тираж б-н (айга 450 меңләп данә) чыга. Укучылар аудиториясен киңәйтергә, милли тәрбия мәсьәләләренә игътибар юнәлтергә омтылып, «С.» төрле бәйгеләр («Гыйффәт туташ», «Киленбикә», «Сөйгәнемә — сөю билгесе» һ.б.) уздыра. 1980 елларның 2 нче яртысында ислам һәм мөселман хатын-кызлары тормышына багышланган материаллар басыла башлый. 1999 да редакция укучылар тарафыннан зур абруй казанган дип табылган хатын-кызларга бүләк («Сөембикә беләзеге») булдыра. Бөтентатар «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы «С.» җирлегендә оеша. «С.» — 1980 еллардан башлап илдән читтә яздырыла торган татар телендәге беренче басма. 2000 еллар башында туташлар өчен аерым «Асылъяр» кушымтасы б-н чыга. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә (1976).

*З.З.Гыйләҗев.*





1-3. «Азат хатын»; 4. «Сөембикә».

**«СӨЕМБИКӘ́ БӘЕТЕ́»**, тарихи бәет. Сюжет нигезендә — Казан ханлыгының соңгы ханбикәсе Сөембикәнең трагик язмышы. Хикәяләү аның исеменннән алып барыла (бәет ул исән чакта язылган дип фараз ителә). Сөембикә туган вакытыннан алып үзе турында сөйли, аеруча Казан чорына игътибар бирә. Хикәяләү тарихи фактларга туры килмәскә дә мөмкин. Бәеттә Сөембикәнең улы Үтәмешгәрәй 6 яшендә үлгән дип бәян ителә; чынбарлыкта ул әнисеннән озаграк яши (татар аксөякләре тарафыннан Сөембикә б-н бергә Иван IV кә тотып бирелә һәм чукындырыла). Бәет үз башкаласын ташлап китәргә һәм Шаһгалигә кияүгә чыгарга мәҗбүр булган Сөембикәнең кайгы-хәсрәте б-н сугарылган. Бәетнең эчтәлеге, лексикасы һәм кайбер сәнгать үзенчәлекләре Сөембикәнең ире Сафагәрәйнең кабере б-н саубуллашкандагы «Казан елъязмасы»нда китерелгән ике елавы б-н аваздаш. «С.б.» беренче тапкыр 20 йөз башында нәшер ителә. Аны өйрәнү б-н Һ.Атласи шөгыльләнә. Татарстан районнарында язып алынган бәет вариантлары ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының кульязмалар мирасханәсендә саклана. Сөембикәнең тарихын бик күп татар язучылары әсәрләрендә файдаланалар (Ф.Бурнаш, К.Юлдаш, М.Фәйзи һ.б.).

*Әд.:* Рәшиди Г. Сөем-Бикә. К., 1912; Татар халык иҗаты: Бәетләр. К., 1983; Урманче Ф. Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә. К., 1997; Сөембикә бәете // Сөембикә ханбикә: Җыентык. К., 2001; Казанская история. М.–Л., 1954.

*Ф.И.Урманчеев.*

**СӨЕМБИКӘ́ МАНАРАСЫ́**, Казан шәһәренең символы булып әверелгән. Кремльнең төньяк-көнбатыш читендәге биек калкулыкта урнашкан корылманың төзелү вакыты 16 йөзнең беренче яртысыннан алып 18 йөзнең беренче чирегe кысаларында тирбәлә. Киртләч-ярусл композиция тәшкил итүче биек корылма булып тора. Югарыга таба бер-берсенә кечерәя бару тәртибендә урнашкан киртләч-киртләч өч дүрткырлык шпиль б-н очланган, сигезкырлы күзәтү ярусл кисек чатыр б-н төгәлләнгән төрле зурлыктагы ике сигезкырлыкны күтәреп тора. Дүрткырлыклар



Сөембикә манарасы. Казан.
16 йөз уртасы – 18 йөз башы. Хәзерге күренеше.

гарәп манараларына хас ачык йөрү мәйданнары булган тәбәнәк парапетлар б-н әйләндереп алынган. Икенче һәм өченче ярусларның түшәмнәре гөмбәзсыман итеп ябылганнар. Манараның түбән ярусы аша үтүче биек аркалы юл диварында эченә гөмбәзсыман түшәмле тар баскычлар урнашкан ян баганалар бар. Манара зур үлчәмле кирпечтән төзелгән, чатыр табаклы калай б-н ябылган. Манараның биеклеге якынча 53 *м* 90 *см* (башка мәгълүматлар буенча — 54 *м* 90 *см*), шпиль б-н бергә — 58 *м*. Манара төньяк-көнчыгышка таба 1,98 *м* га авышуы б-н дә мәгълүм.

Вертикаль торышыннан авыша башлау сәбәпле, 1914–16 елларда манарада реставрация эшләре үткәрелә, түбәнге ярус киң, корыч пута б-н ныгытыла. Башта очына ике башлы сәмруг кош билгесе, 1918 дән — көмеш ай, 1934 тән — шпиль, 1993 тә алтынланган ай беркетелә. 1958–59, 1970 һәм 1980 еллар ахырында реставрацияләнә.

Манараның төзелү вакытын төрле чорларда төрле авторлар йә татарлар урта гасырларына, йә яңа чор Россиясенә (18 йөз) бәйләп карыйлар. Сөембикә манарасының Казан ханлыгы архит-расы культурасы кысаларында ислам чорында төзелү ихтималлыгы автор гипотезасында бәян ителә. Ул елъязма, тарихи, археол., архит-ра, картография, ислам һ.б. чыганакларны анализлауга таянып нигезләнә, Россия югары уку йортында (Казан дәүләт архит-ра-төзелеш ун-тында яклау табып), студентлар тарафыннан өйрәнелә.

Казан татарларының телдән-телгә күчеп яшәп килгән риваятьләренә караганда, манара XVI йөзнең уртасына кадәр, хан сараена үткәрүче капка өсте манарасы буларак, *Сөембикә* ханбикә тарафыннан ире *Сафагәрәй хан* кабере өстенә төзелгән. Сөембикә манарасының татар чыгышлы булуын яклаучылар арасында Ш.Мәрҗани, 1877; К.Насыйри, 1860; С.М.Шпилевский, 1877; Р.В.Егерев, 1941; Р.Г.Фәхретдинов, 1990; Ф.В.Салихова, 2001; Г.Н.Айдарова-Волкова, 2012 һ.б. бар.

Башка төркем манараны Казан архит-расы үсешенең Россия чорына бәйли:

– манара 17 йөздә төзелгән (В.В.Суслов, 1880; И.Грабарь, 1914; Н.Ф.Калинин, 1930;

– манара 18 йөздә, Казан губернасы оештырылганнан соң, комендант йортына кирмән манарасы буларак төзелгән (М.Рыбушкин, 1849; М.Худяков, 1923; С.С.Айдаров, 1989; А.Х.Халиков, 1988;

– манараның беренче өч ярусы — ханлык, калган өч өлеше Россия чорында корылган (И.Д.Андреевский, 19 йөз; П.Невзоров, 1894; Ф.Х.Вәлиев, 1986).

Шунысын да әйтергә кирәк: Казан Кремлендә 1555 тән алып бүгенге көннәргә кадәр барлык эре объектларның төзелү тарихлары документаль нигездә билгеле. Алар арасында Сөембикә манарасының исеме генә юк. Бу факт мәһабәт манараның Казан ханлыгы чорында төзелүе һәм яшәве турында сөйли.

*Әд.:* Урманче Ф. Сөембикә бәете // Казан утлары. 1997. № 8; Катанов Н.Ф. Исторические песни Казанских татар // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1899. Т. 15, вып. 3; Фехнер М.В. Великие булгары. Казань. Свияжск. М., 1978; Памятники истории и культуры Казани. К., 1982; Саначин С. Возраст Сююмбекиной башни // Казань. 2002. № 9; Айдарова-Волкова Г.Н. Архитектурная культура Среднего Поволжья XVI–XIX веков. К., 1997; шул ук. Архитектурно-градостроительное развитие Казани X–XVI веков. К., 2012.

*Г.Н.Айдарова-Волкова.*

**СӨЕНДЕ́К** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 35 *км* көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 190 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, иткә терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. Мәчет. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, капчык-чыпта сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.тә 2 мәчет, 2 мәктәп, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2485 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Эстәрлетамак волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1816 да — 95 ир-ат; 1859 да — 445, 1889 да — 843, 1897 дә — 948, 1910 да — 1174, 1920 дә — 731, 1926 да — 470, 1938 дә — 554, 1949 да — 414, 1958 дә — 353, 1970 тә — 272, 1979 да — 275, 1989 да — 199, 2002 дә — 208 кеше.

**СӨЕНДЕ́К** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 58 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зөя елгасы буенда. 2010 елда 319 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт һәм удел (1830 лардан) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, лашманчы хезмәтен үти. 1863 елгы мәгълүматларга караганда, С.тә мәчет була, 1897 дә мәдрәсә ачыла. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; 2 мәчет, 2 мәдрәсә, 10 сәүдә-сәнәгать бинасы эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 458,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Сембер өязе Сөендек волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Буа, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 705, 1897 дә — 1079, 1913 тә — 1355, 1920 дә — 1498, 1926 да — 1612, 1938 дә — 1571, 1949 да — 1135, 1958 дә — 869, 1970 тә — 1218, 1979 да — 584, 1989 да — 416, 2002 дә — 350 кеше.

**СӨЕНДЕ́К ФОСФОРИТЛА́Р ЧЫГАНАГЫ́**, Тәтеш р-ны Сөендек авылыннан көньяктарак урнашкан. Тикшерү эшләре 1931 елда башлана, 1983–85 тә төгәлләнә. Сәнәгый ятмалар югары юра һәм түбән акбур утырмаларына туры килә; мәйданы 90 *га* дан артык; ачылма токымнарның калынлыгы 16,3 *м* га кадәр, фосфорит катламы — якынча 1 *м*; рудаларда $P_2O_5$нең уртача күләме 11%. $A+B+C_1$ категориясе буенча руда запаслары якынча 224,3 мең *т*, $P_2O_5$ 24,9 мең *т* тәшкил итә. 2005 елга кадәр үзләштерелә.

*Әд.:* Агроминеральные ресурсы Татарстана и перспективы их использования. К., 2002.

**СӨЕНДЕ́КОВ** Мөхәммәдшакир Габденәфыйк угылы (19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башы), язучы, ахун. Вятка губернасы Сарапул өязе Әгерҗе авылында имам булып тора. «Китабел-васыйәт» («Васыйәтләр китабы», 1897), «Ысуле тәдрис» («Дәрес бирү ысуллары», 1899), «Корбан рисаләсе» һ.б. дини-дидактик әсәрләр авторы. Башка җәдитче авторлар б-н беррәттән Г.*Фәезхановның* «Мөхәррикел-әфкяр» («Фикерләр уяткыч», 1893) хезмәтендә телгә алына.

*М.В.Гайнетдинов.*

**СӨЗӘКЛЕКЛӘ́Р АСИММЕ́ТРИЯСЕ**, елга үзәне, субүләр, сыза һәм ерымнарның капма-каршы битләүләренең бер үк текәлектә булмавы. Татарстан терр-ясендә киң таралыш алган. С.а. зур елга (Идел, Кама, Вятка) үзәннәрендә, Җирнең үз күчәре тирәсендә әйләнүе нәтиҗәсендә туган көч тәэсирендә елга юлының озак еллар дәвамында (2–3 млн. елдан да ким түгел) шактый гына уң якка күчә баруы (мәс., Тәтеш шәһәре янында 50 *км* га) б-н бәйле. Үзәннәрнең юылучы уңъяк битләүләре текә (15–30°), төп токымнардан тора; сулъяк битләүләрдә төрле биеклектәге тугай өсте террасалары формалашкан, аларда Казан, Чаллы, Түбән Кама, Яшел Үзән шәһәрләре урнашкан. Бу елгаларның сул яктагы тугайлары уң яктагыдан 2–3 тапкыр зуррак булган. Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары төзелү б-н ТР терр-ясендә зур елга юлларының авышуы туктала. Уртача зурлыктагы күп кенә елгаларның (Ык, Иж, Зәй, Чишмә, Зөя, Олы Чирмешән, Казансу, Үләмә, Кылна) үзәннәре дә шушындый типтагы С.а.нә ия, әмма алардагы елга юлларының уң якка авыша баруы зур булмый һәм нигездә, үткән геол. чорларда бара. Кече елга үзәннәрендәге кисәк күзәтелүче С.а.нең килеп чыгышы үзгә. Ул бозлык чорында мәңгелек туңлык һәм салкын климат шартларында төрле экспозицияле тау битләрендә интенсивлыгы төрлечә булган *солифлюкция* тәэсирендә формалаша. Көньякка һәм көнбатышка караган яхшы җылынучан тау битләре текәрәк (20–30°). Каршы як битләүләр сөзәк (2-3°), лёссыман комсыл балчыклардан тора, аларда исә уңдырышлы туфраклар үсеш алган. Елга үзәннәренең С.а. асимметрияле субүләрләр формалашуга китерә. Сөзәклекләрнең юнәлеше һәм текәлегенә бәйле рәвештә аларның термик режимы һәм дымлылыгы бертөрле түгел, туфрак һәм үсемлек капламы да төрле. С.а. ерымнарда җиңелчә генә күзәтелә, күләгәдәге дымлы битләүләр тизрәк шуыша һәм тигезләнә.

*Әд.:* Сементовский В.Н., Батыр В.В., Ступишин А.В. Рельеф Татарии. К., 1951; Дедков А.П. Экзогенное рельефообразование в Казанско-Ульяновском Приволжье. К., 1970; Бабанов Ю.В. Формирование и развитие асимметрии склонов речных долин Среднего Поволжья. К., 1989.

*А.П.Дедков.*

**СӨЙКЕ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Бырыс елгасының (Кама елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 10,3 *км*, бассейнының мәйданы 68,8 *км*$^2$. Лаеш р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Урта Девятово авылыннан 1,6 *км* төньяктарак, тамагы Чырпы авылында. Елга башының абс. биеклеге 90 *м*, тамагыныкы — 55 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25%. С.нең 0,2 дән 5,4 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,24 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 72 *мм*, ташу агымы катламы 66 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,026 *м*$^3$*/с*. Коры вакытта елга кибә, су бары тик елганың тирән урыннарында гына кала. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. С. бассейнында суының гомуми күләме 0,2 млн. *м*$^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**СӨЙКЕ́** (Сөйки) авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 23 *км* көньяк-көнбатыштарак,

Мордвасу елгасы буенда. 2010 елда 654 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Кокеево исеме б-н дә билгеле. 1646 дан татар авылы буларак мәгълүм. 1720 елларда бу җирләрне йомышлы татарлар Сюкеевлардан Казан архиерей йорты сатып ала, һәм монда рус крәстияннәре килеп урнаша (1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә). Халкы игенчелек, бакчачылык, терлекчелек, атлар үрчетеп сату, май язу, он тарту, тимерчелек, кирпеч сугу, йон-тукыма ману, балта эше, сарык тиресе эшкәртү, йон тетү, известьташ табу һәм эшкәртү, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.дә волость идарәсе урнаша; Троица чиркәве (1813 тә төзелә; архит-ра истәлеге), иске дин тарафдарлары гыйбадәтханәсе, земство мәктәбе (1866 да ачыла), алебастр з-ды, 23 җил тегермәне, 4 тимерчелек, 4 йон тетү, 3 май язу, 4 сарык тиресе эшкәртү һәм 2 йон-тукыма ману йорты, 5 чәйханә, 2 сыраханә, 1 казна шәраб, 2 мануфактура-бакалея һәм 14 вак-төякләр кибете, пароходлар пристане була; пәнҗешәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 6020 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Сөйке волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1646 да — 63, 1782 дә — 325 ир-ат; 1834 тә — 2523, 1859 да — 2531, 1897 дә — 3567, 1908 дә — 3746, 1920 дә — 3706, 1926 да — 3161, 1938 дә — 2411, 1949 да — 1902, 1958 дә — 1750, 1970 тә — 988, 1979 да — 930, 1989 да — 792, 2002 дә — 674 кеше.

**СӨЙКЕ́ КИЧҮЕ́** посёлогы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 27 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 4 кеше (руслар) яши. 1926 да нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Тәтеш р-ны Тәтеш волостенда, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1938 дә — 40, 1970 тә — 45, 1979 да — 34, 1989 да — 17, 2002 дә — 9 кеше.

**СӨЙКЕ́ КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Идел елгасының уңъяк ярындагы ерымнар б-н әйләндереп алынган борынында, Кама Тамагы р-нының Сөйке Кичүе посёлогыннан 3,5 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. С.к. истәлекләре 1928 елда Н.Ф.Калинин, 1968 дә М.Г.Косменко, 1980–90 да М.Ш.Галимова, 1990 елларда А.М.Гобәйдуллин тарафыннан тикшерелә. Мезолит, энеолит чорлары туктаулыкларын, Ананьино һәм Азелино культураларына нисбәтле авыллыкларны, Азелино культурасына караган «Чәчле күл» каберлеген, Имәнкискә һәм Болгар (Алтын Урда) культуралары шәһәрлекләрен һ.б.ны үз эченә ала. 21 йөз башына кадәр борынның төрле өлешләрендә 600 $м^2$ дан артык культура катламы ачылган.

Мезолит һәм энеолит чорлары таш эшкәртү туктаулык-остаханәсендә *Чулман тамагы культурасының* элгәреге чорына караган күпсанлы чакматаш, чакматашка әверелгән известьташ һәм кварцит эшләнмәләр (барлыгы 20 меңгә якын) табыла. Таш инвентарь эре пластиналардан эшләнә, алар чакматаш кисәкләрен махсус ваткалау алымнары куллану нәтиҗәсендә әзерләнә. Пластиналардан читләрен һәм өслекләрен яссы шомарту, кителеп төшкән урыннарны тигезләү һәм очлыкларын юну ярдәмендә кискеч тешләр, беркеткечләр, ышкылар, өтергеләр һәм вак өтергеләр, ш.у. зур чапкыч кораллар һәм кыргычлар эшлиләр. Туктаулыкта яшәүчеләр пластина кисәкләрен хезмәт һәм сугыш коралларына өстәмә детальләр буларак киң кулланганнар. Трапеция рәвешендәге, яклары шомартылган мондый өстәмәләр Волосово культурасына нисбәтле «Сөйке Кичүе» туктаулыгында табыла. Борынның төньяк-көнчыгыш чигендә ташны китеп эшкәртү ярдәмендә ике ягы да шомартылган кораллар (бифас дип тә йөртелә) җитештерү өчен күпсанлы әзерләмәләр һәм китек-калдыклар, ш.у. чакматаш һәм кварциттан эшләнгән ук һәм кыска сөңге очлыклары, чакматаш балталар, аркылы балталар, төрле кыргычлар һәм кискеч кораллар булуы билгеләнә. Болгар чоры Сөйке шәһәрлеге (мәйданы 12,5 *га*) борынның чокырга параллель төньяк-көнчыгыш өлешеннән үткән икешәр рәт урлар һәм ерымнар б-н саклана. Шәһәрлекнең кыр ягыннан корылган төп ныгытмалары соңрак сөрелә. Казулар барышында истәлекнең яр буе өлешендә 3 торак һәм 20 дән артык хуҗалык чокырлары калдыклары ачыклана. Аның терр-ясендә чүлмәк ясау түгәрәгендә һәм әвәләп ясалган («славяннарга хас») болгар савыт-саба ватыкларының, тимер хезмәт кораллары, ук очлыклары, бронза казаннар һәм сөяк әйберләр фрагментларының зур тупланмасы, ш.у. 1280–1350 елларга нисбәтле Алтын Урда акчалары табыла. Сөйке шәһәрлеге Болгар һәм Алтын Урданың һөнәрчелек һәм сәүдә үзәкләренең берсе була.



«Сөйке Кичүе» туктаулыгы культура катламыннан югары палеолит–мезолит дәверләре чакматаш кораллары.

*Әд.:* Калинин Н.Ф. От Сюкеева к Камскому Устью (Археологические разведки) // Зап. Тетюш. музея. 1928. Вып. 3; Археологическая карта Татарской АССР. Предволжье. К., 1985; Галимова М.Ш. Памятники позднего палеолита и мезолита в устье реки Камы. М.–К., 2001; Галимова М.Ш., Губайдуллин А.М. Краткие итоги исследования Сюкеевского городища // Из археологии Поволжья и Приуралья. К., 2003.

*М.Ш.Галимова.*

**СӨЙЛӘ́Ш**, телнең, гадәттә, бер яки берничә күрше авыл, торак пунктларда яшәүче кешеләр тарафыннан кулланыла торган һәм тел төзелешенең төрле үсеш баскычында кайбер үзенчәлекләргә ия булган бер төре. Гамәлдәге бу тел системасы башка С.ләр системасыннан үзенең фонетик, грамматик, сүз ясалыш һәм лексик үзенчәлекләре б-н аерылып тора. Төрле җирләрдән җыелган кешеләрдән оешкан торак пунктта төрле С.ләр күзәтелә. *Ареаль лингвистикада* С. — лингвистик киңлектәге нокта, аңа С.ләр төркеменнән һәм *диалекттан* торган ареаль берәмлекләр каршы куела. Теге яки бу С. вәкилләре һәм әйләнә-тирәдә яшәүчеләр арасында элемтә булмаганда (тел, мәдәният, диннәр арасында көчле аерма күзәтелгәндә), әлеге С. вәкилләре үзләренең гадәти яшәү рәвешләрен актив рәвештә сакларга омтылганда, үзгәрешләр бик әкрен бара, өлкән һәм яшь буын телендә аерма зур булмый. Әдәби тел һәм башка С.ләрнең көчле йогынтысын кичергән С.тә халыкның төрле төркемнәре сөйләменә хас традицион һәм яңа катламнар аерылып чыга. Татар С.енең охшаш, әмма кайбер аермаларга ия булган төркемнәре *көнчыгыш диалект, урта диалект* һәм *мишәр диалектына* берләшә.

*Әд.:* Җәләй Л. Татар диалектологиясе. К., 1947; Татар теленең диалектологик сүзлеге. К., 1993; Татар халык сөйләшләре. К., 2008; Рамазанова Д.Б. Татар сөйләшләрендә кешегә бәйләнешле лексика. К., 2013; Тумашева Д.Г. Диалекты сибирских татар. К., 1977; Ахатов Г.Х. Мензелинский говор татарского языка // Диалекты и топонимия Поволжья. Чебоксары, 1981; Рамазанова Д.Б. Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. К., 1984; Садыкова З.Р. Говоры оренбургских татар. К., 1985; Хайрутдинова Т.Х. Говор златоустовских татар. К., 1985; Баязитова Ф.С. Говоры татар-кряшен в сравнительном освещении. М., 1986.

**СӨЙРӘЛҮЧЕЛӘ́Р**, рептилияләр (Reptilia), умырткалы хайваннар классы. С. коры җир экосистемасында палеозой ахырыннан (Пермь) кайнозой башына кадәр, ягъни 150 млн. ел өстенлек итәләр. Диңгезләрне (ихтиозаврлар, плезиозаврлар һ.б.) һәм һава мохитен (птерозаврлар, птеродактиллар) үзләштергәч, С. мезозойда аеруча үсеш алалар. Җир өстендә һәм ярымсуда яшәүче иң зур С.нең — динозаврларның озынлыгы 30 *м* га җитә. Барлык санап үтелгән мезозой С.е төркеменең үлеп бетүе мезозойдан кайнозойга күчү чорына туры килә, биосфераны аларның үсә баручы буыны — имезүчеләр һәм кошлар алыштыра. Хәзерге С. — бай һәм күптөрле рептилияләр дөньясының калдыклары, аларның озынлыгы 45 *мм* дан (хамелеон брукезия) 11 *м* га (анаконда еланы) кадәр.

Борынгы С.нең скелетлары тулысынча диярлек сөяккә әйләнгән. Баш сөяге б-н умырткасы бер бүлтәймә ярдәмендә тоташа, аны өстән һәм ян-яктан сөяк капламы чорнап алган; чигә тирәсендә алар редукцияләшкән һәм бер яки ике чигә җәясе б-н бүленгән тешемнәр хасил итәләр. Очлыклары биш бармак рәвешендә (күп кенә төркемнәрнең бармаклары яки барлык очлыклар редукцияләшергә мөмкин). Күп кенә С.нең (ташбакалардан кала) кабыргалары, күкрәк сөяге б-н тоташып, күкрәк читлеге хасил итәләр һәм сулыш алуның кабырга тибын тудыралар. Баш мие югары төзелешле умырткалыларга караганда азрак үсеш алган, ләкин катлаулы хәрәкәт координациясен тәэмин итүче кечкенә ми үскән. 2 кан әйләнеше түгәрәге, өч камералы (2 йөрәгалды һәм 1 йөрәк карынчыгы) яки дүрт камералы йөрәк (крокодилларда). Трахея, бронхлар, күзәнәкле үпкә, күпчелегендә — бәвел куыгы, ата С.дә (гаттериядән тыш) копуляция органы (ул елан һәм кәлтәләрдә парлы) бар. Тәннәре мөгез кабырчыклар һәм калканчыклар (йомшак тәнле су ташбакаларыннан кала) б-н капланган. Тире бизләре аз яки бөтенләй юк. С.не 6 асклasска бүлеп йөртәләр: тулысынча үлеп беткән синаптозаврлар, ихтиоптеригийлар һәм ерткыч хайвансыманнар (борынгы имезүчеләр), анапсидалар (хәзерге ташбакалар), архозаврлар (хәзерге крокодиллар) һәм тәңкә тиреле кәлтәләр (хәзерге гаттерия һәм кәлтәләр, еланнар). С.нең 16 отряды үлеп беткән, 4 се (7820 төр) сакланган, алар Антарктидадан кала барлык континентларда яши. Крокодиллар һәм күп кенә ташбакалар төче сулыкларда, кайбер еланнар һәм ташбакалар — диңгездә, күпчелеге — җирдә яшиләр. Россиядә 79 төр, Идел-Кама чикләрендә — 11, Татарстан терр-ясендә — 8: ташбакалар отрядыннан 1 төр һәм тәңкәтиреләләр отрядыннан 7 (кәлтәләрнең — 3, еланнарның 4 төре). С.нең тән темп-расы күпмедер дәрәҗәдә тирәлеккә, барыннан да бигрәк, субстратка бәйле. Эчке аталану хас, кайбер кәлтә һәм еланнарда партеногенез (күкәй күзәнәгенең аталанмыйча үсүе) күзәтелә. Күпчелек С. йомырка салып үрчи, кайберләре йомыркадан тереләй тудыручылар (бакыр кәлтәләр, тереләй тудыручы кәлтә, *бакыр елан*) яки тереләй тудыручылар (гади *кара еланнар*). Йомыркалары сарыга бай һәм кибүдән саклаучы каты известьле (мәс., ташбакалар) яки пергаментсыман (тәңкәтиреләләр) тышча б-н капланган. Инкубация чоры бер айдан бер елга кадәр дәвам итә. Буын турында кайгырту йомырка салу урынын сайлау б-н бәйле (гади тузбашның — чери башлаган яфрак, тирес). Күп кенә С. — бөҗәк ашаучылар һәм ерткычлар — умырткалылар һәм бөҗәкләрнең киң таралган төрләрен көйләүдә катнаша, җир өстендә яшәүче ташбакалар — фитофаглар, кәлтәләр — туклануда талымсыз. Борын-борыннан кеше С.не азык буларак (ит, йомырка), көнкүреш һәм бизәнү әйберләре (тире, панцирь) ясауда куллана. 5 төре (*саз ташбакасы*, бакыр кәлтә, бакыр елан, гади һәм дала кара еланнары) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Г а р а н и н В.И. Земноводные и пресмыкающиеся Волжско-Камского края. М., 1983; Жизнь животных. М., 1985. Т. 5; Г а р а н и н В.И., П а в л о в А.В. Герпетология. К., 2002. Ч. 2.

*В.И.Гаранин.*

**СӨЙУРГА́Л** (төрки-монголча сөйурга(мак), сүзгә-сүз тәрҗемәдә — бүләкләү, рәхим-шәфкать күрсәтү), хәрби яки адм. хезмәт башкару шарты б-н җирне мирас итеп калдыру. Хәрби-лен системасының бер төре буларак С. ин-ты Монгол империясенең көнбатыш олысларында (Җүчи, Чагатай, Һулагу олыслары) һәм Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән татар ханлыкларында оеша һәм хөкем сөрә. 16–19 йөзләрдә С. Иран, Һиндстан һ.б. илләрдә таралыш ала. С. алганда рәсми документ — бер яки берничә кеше исеменә хан ярлыгы да бирелә. С. иясе салым түләүдә, мәхкәмә-адм. эшләрендә өстенлекләрдән файдалана. Үзенә буйсынган халыктан үз файдасына салым җыйганда, аның язмышын хәл иткәндә, ул чынлыкта удел идарәчесенә әверелә. Күләме буенча С. кечерәк җир биләмәләре булган авылны, аерым очракларда күп кенә торак пунктлар кергән зур өлкәләрне колачлаган. 15–16 йөзләрдә татар ханлыкларында хәрби-адм. аксөякләр дә, ш.у. руханилар да С. хуҗасы була алган (к. *Сәхибгәрәй хан ярлыгы*). Ш.у.к. *Тархан.*

*Әд.:* М у х а м е д ъ я р о в Ш.Ф. Земельные правоотношения в Казанском ханстве. К., 1958; П е т р у ш е в с к и й И.П. Земледелие и аграрные отношения в Иране XIII–XIV вв. М.–Л., 1960; У с м а н о в М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. К., 1979.

*М.Г.Госманов.*

**СӨЛӘ́Й** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 35 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Урсалы елгасы буенда. 2010 елда 759 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1746 дан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, каеш сбруй әйберләре — ияр ясау б-н шөгыльләнә. 1885 тә С.дә крәстиян чуалышлары (к. *Сөләй крәстияннәре кузгалышы*) булып уза. 20 йөз башында С.дә земство станциясе урнаша, 2 мәчет, 2 мәктәп, 2 су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете була; базар эшли (1898 дән). Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2144 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мәсгут волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1746 да — 5, 1762 дә — 18 ир-ат; 1795 тә — 236 кеше, 1816 да — 152 ир-ат; 1859 да — 799, 1889 да — 1235, 1897 дә — 1251, 1910 да — 1566, 1916 да — 1551, 1920 дә — 2225, 1926 да — 1461, 1938 дә — 1240, 1949 да — 1078, 1958 дә — 1676, 1970 тә — 1120, 1979 да — 940, 1989 да — 678, 2002 дә — 788 кеше.

**СӨЛӘ́Й КРӘСТИЯННӘРЕ́ КУЗГАЛЫШЫ́**, 1885 елда Самара губернасы Бөгелмә өязенең татар авыллары крәстияннәре чуалышлары. С.к.к.ның турыдан-туры сәбәбе булып хакимияттәгеләрнең йорт хайваннары чумасы таралуга каршы юнәлдерелгән вет. стражникларын тотуны халык өстенә йөкләтү, крәстияннәрдән 1,5 процент өстәмә салым түләтүне кертү һ.б. чараларны гамәлгә ашыруы тора. Бу чараларга җавап итеп, 1884 тә Самара губернасының Самара, Николаевск һәм Бөгелмә өязләренә кергән кайбер авыл крәстияннәре «чума комиссияләре»н кабул итүдән баш тарталар, мал санын исәпкә алуга каршы торалар, стражникларны куалар һ.б.ш. Крәстияннәрнең яңа салымнардан канәгатьсезлеген мөселманнарны христианлыкка күчерүнең яңа дулкыны турындагы сүзләр таралу көчәйтә. Бөгелмә өязендә крәстияннәр чуалышы бөтен волостьны диярлек чолгап ала, Сөләй авылында ул аеруча зур куәт ала. 1885 нең май башында анда яшәүчеләр авыл җыенында өяз исправнигына стражникны үз акчаларына тоту һәм салымнар түләүгә каршы булуларын белдерәләр. Халыкны көч кулланып тараталар, әмма алар икенче көнгә күрше Урсалыбаш һәм Шарлама авыллары халкы б-н бергә җыелалар. Исправникларның үгетләүләре нәтиҗә бирми. Крәстияннәр стражникларны гына түгел, стан приставы б-н исправникны да куу б-н яныйлар. Соңрак Сөләй авылына полиция отряды озатуында прокурор б-н тикшерүче килә. Тик крәстиян чуалышы җитәкчеләрен кулга алырга омтылыш барып чыкмый. 18 майда авылга губернатор А.Д.Свербеев һ.б. вәкаләтле затлар килә. Губернаторның авыл җыеныдагы гамәлләре (кайбер крәстияннәрне кыйнау, кулга алу) җыелган халыкның ачуын китерә. Тезләнергә теләмичә, алар сәнге, таяк, балта б-н коралланып, губернатор, чиновниклар һәм полицейскийлар өстенә ташланалар. Баш күтәрүчеләр ягыннан «Китегез, юкса үтерәбез...», «безгә стражниклар да, чума комиссиясе дә кирәкми, салымнарны да түләмәячәкбез», «стражникны кертмибез» һ.б. кебек сүзләр ишетелә. Губернатор б-н чиновниклар китәргә мәҗбүр булалар; крәстияннәрне бастыру өчен бер батальон солдат җибәрәләр, крәстияннәрне 1,5 процентлы салым түләргә мәҗбүр итәләр, мал санын исәпкә алалар. 26 кешене — Сөләй, Урсалыбаш, Шарлама, Яңа Кәшер, Минзәләбаш халкын судка бирәләр, 18 кешене төрле җәзага хөкем итәләр, кузгалышның төп оештыручысын — Г.Әдһәмовны Себергә сөрәләр.

*Әд.:* Б а й р а м о в К.Л. Сулеевское восстание 1885 года // Тр. КФАН СССР. 1959. Вып. 2; Р а ф и к о в а Г. «Волнение возникло из заблуждений и ошибок...» (Сулеевское восстание 1885 г.) // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2004. № 2.

**СӨЛӘЙМА́Н**, Коръән персонажы, тәкъва һәм зирәк патша, Дауд патша улы; Библиядәге Соломонга туры килә. Исламга кадәрге Гарәбстанда ук билгеле була. Коръән буенча, яшьтән үк этисе б-н кул астындагы кешеләрнең бәхәсләрен хәл итә, зирәклектә әтисен уздыра һәм аның тәхетен мирас итеп ала. С. Аллаһы Тәгаләгә инана һәм аңардан куркучы була, шуның өчен Аллаһ аны хикмәтле көч, яшерен магик белем һәм хайваннар телен аңлау куәте б-н зурлый. С. табигать, җеннәр һәм *шайтаннар* көчен үзенә буйсындыра. Алар С. өчен диңгез төбеннән хәзинә чыгаралар, храмнар төзиләр. Коръәндә С.ның моңарчы үз халкы б-н кояшка табынучы патшабикә Мәликәт Сабаны Аллаһка ышаныр-



Ә.Н. Сөләйманов.

га күндерүе турында бәян бар. С. агач таякка таянган хәлдә вафат була, кортлар таягын кимереп бетергәнче, гәүдәсе басып тора. Коръәннән соңгы риваятьләрдә С. Аллаһы Тәгалә бүләк иткән балдактан килүче көчкә ия булган бөек тылсымчы буларак сурәтләнә. С. образы һәм ул тудырган могҗизалар урта гасырлар мөселман әдәбияты һәм фольклорында нигез итеп файдаланыла.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. К., 1991.

**СӨЛӘЙМА́Н** бине Дауд (әс-Саксини әс-Сувари) (12 йөз), болгар әдибе һәм илаһият галиме. *Әбу-л Галә Хәмид бине Идрис әл-Болгари* шәкерте. «Серләр хакыйкатен нур ачар» («Бәһҗәт әл-әнвар мин хәкыйкать әл-әсрар»), «Сырхау күңелләрне сихәтләүче» («Нөзһәт әл-колүб әл-мәраз»), «Авыруларның күңелләрен дәвалаган чәчәк бакчасы» («Зөһрәт әр-рийаз вә нөзһәт әл-колүб әл-мәраз») үгет-нәсыйхәт һәм әдәби әсәрләрендә үзенең остазы вәгазьләрен тәфсилләп сурәтли.

*Г.М.Дәүләтшин.*

**СӨЛӘЙМА́Н БАЛЫКЛА́Р** (Salmonidae), сөләймән балыксыманнар отрядыннан балыклар семьялыгы. 8 ыругны, 30 дан артык төрне үз эченә ала. С.б. — Төньяк ярымшарның кереп йөрүче һәм төче су балыклары; Евразиядә, Төньяк Америкада һәм Төньяк Африканың тау инешләрендә яшиләр. Гәүдәсе тыгыз тәңкәләр б-н капланган. Бер арка һәм бер майлы йөзгече бар. Арка йөзгечендә нурлар 10 нан 16 га кадәр, майлы йөзгечтә нурлар юк. Уылдык бөртекләре эре, кызгылтсары төстә. ТР терр-ясендә 2 төре бар: таймень (Hucho taimen) һәм *инеш керкәсе* (Salmo frutta). Таймень сирәк очрый, Куйбышев сусаклагычының Кама тармагында тотылган очраклары билгеләнгән. Зур балык, озынлыгы 1 *м* дан, авырлыгы 60 *кг* нан артык. Уылдыгын язын кече елгаларның чуер ташлы грунтына чәчә. Уылдыгы эре, үрчемлелеге — 10–34 мең уылдык бөртеге. Яшәвенең 4–6 елында җенси яктан җитлегә. Ерткыч, уылдыгын чәчкәннән соң, нык кына симерә, аннан соң җәен бөтенләй диярлек тукланмый. Инеш керкәсе чиста һәм салкын сулы инешләрдә һәм зур булмаган елгаларда (Зәй, Бөрсет, Кече Шомбыт, Ильинка) яши. Буларда ясалма рәвештә үрчетү объекты. Ике төре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**СӨЛӘЙМА́Н МӨҺЕРЕ́**, бүре борычы (Polygonatum), лаләчәләр семьялыгыннан үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 гә якын төре билгеле, күбесенчә Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. ТРда 2 төре бар: күп чәчәкле С.м. (P. multiflorum) һәм дарулы (хуш исле) С.м. (P. odoratum). Республиканың барлык терр-ясендә очрый. Киң яфраклы һәм ылыслы-киң яфраклы урманнарда, куаклар арасында үсәләр. 15–100 *см* биеклектәге үсемлекләр. Тамырчасы горизонталь, җир өсте ботакларының түгәрәк батынкы җөйләр — «мөһер» калдырып корыган урыннарында юанаеп тора. Дарулы С.м.нең сабагы кырлы, күп чәчәкле С.м.нең цилиндрсыман. Яфраклары чиратлашкан, ланцетсыман яки озынча түгәрәк-эллиптик, ике яклап дугасыман бөгелгән сабакларда. Чәчәкләренең күп өлеше яшькелт-ак төстә, яфрак куентыгында урнашканнар. Дарулы С.м. 1–2, күп чәчәкле С.м. 2–5 чәчәкле. Җимеше — 1–2 орлыклы зәңгәрсу-кара җиләк. Май–июньдә чәчәк аталар. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Дарулы С.м.нең тамырчасында алкалоид, сапонин, лайла, С витамины бар. Халык медицинасында тамырчаларыннан ясалган төнәтмә бронхиттан, үпкә ялкынсынуыннан, эчке органнар җәрәхәте, баш авыруларыннан кулланыла. Үсемлекнең барлык өлешләре дә (аеруча җимешләре) костыру үзлегенә ия. Декоратив, баллы, агулы үсемлекләр.

**СӨЛӘЙМА́НОВ** Альфред Мидхәт улы (19.12.1952, Әтнә р-ны Олы Әтнә а.), төзелеш материаллары өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2007), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2008). 1977 елда Казан төзүче инженерлар ин-тын (хәзер Казан архит.-төзелеш ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук, төзелеш материаллары кафедрасында эшли, проректор (2006 дан), проф. (2008). Төп тикшеренүләре материаллар һәм эшләнмәләрнең озакка чыдамлыгын фаразлауга; композицион материалларның искерүен һәм җимерелүен матем. (ш.и. күп үлчәнешле) модельләштерүгә карый. С. төзелеш материалларына тизләтелгән сынаулар үткәрү буенча методикалар эшли; эксплуатация факторларының (кояш радиациясе, темп-ра, дымлылык, механик йөкләнешләр) тәэсирен модельләштерү җайланмалары сериясен булдыра. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Работа, старение и разрушение материалов ограждений мягких оболочек // Строительные материалы. 2005. № 11; Хемометрический подход к анализу зависимости эксплуатационных показателей полимерных композиций от их состава // Башк. хим. журн. 2005. Т. 12, № 3; Моделирование поведения плёночно-тканевого материала при воздействии эксплуатационных факторов // Механика композиционных материалов и конструкций. 2005. Т. 11, № 4 (автордаш).

**СӨЛӘЙМА́НОВ** Асаф Ибраһим улы (10.6.1938, Бөгелмә ш.), геолог-геофизик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994), геол.-минерал. фән. канд. (1970), ТРның атказ. геологы (1994). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1963). 1964 елдан «Башнефть» ҖБдә эшли. 1970 тән ТатНИПИнефтьтә, нефть чыганакларын эшкәртү бүлеге башлыгы (1981–2002). Дәүләт бүләге авыр чыгарылучы нефть запасларын эшкәртүнең югары нәтиҗәле комплекслы системасын булдырганы өчен бирелә.

**СӨЛӘЙМА́НОВ** Әбҗәлил (? — 1774 нең июне, Казан губ., Казан өязе Тирсә а.), 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышында* катнаша, отряд командиры, баш күтәрүчеләр полковнигы. Алпавыт О.А.Тәфкилевнең Казан өязе Тирсә волосте Тоба авылы крәстияне. 1773 нең декабрендә, крәстияннәр вәкиле буларак, крәстияннәрне крепостной бәйлелектән азат итү турындагы фәрман алу өчен Минзәлә төбәгенә, баш күтәрүчеләр старшинасы К.*Моратовка* бара. Баш күтәрүчеләр боерыгы б-н старшина итеп билгеләнә; Тирсә волостенда крәстияннәр үзидарәсен җитәкли (1774 нең гыйнвар–май айлары). Крәстияннәрне Е.И.Пугачёв фәрманнары һәм манифестлары б-н таныштыра, баш күтәрүчеләр гаскәрләрен тәэмин итү һәм тулыландыру б-н шөгыльләнә. С. отряды 1774 нең 11 маенда Тирсә авылыннан 18 чакрым ераклыкта хәрби команда тарафыннан тар-мар ителә; С. кулга алына һәм Казандагы яшерен комиссиягә җибәрелә. Тирсәдә җәзалап үтерелә.

*Әд.:* А л и ш е в С.Х. Татары Среднего Поволжья в пугачёвском восстании. К., 1973.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**СӨЛӘЙМА́НОВ** Әхмәт Нурмөхәммәт улы (14.11.1923, Әстерхан өлкәсенең Идел буе р-ны Каргалы а. – 1993), Дан орденының тулы кавалеры (29.3.1944, 18.8.1944, 31.5.1945), ефрейтор. Туган авылында колхозда эшли. 1941 елның октябреннән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 352 нче аерым разведка ротасы разведчигы (28 нче һәм 5 нче удар армияләрнең 295 нче укчы дивизиясе). Көньяк-Көнчыгыш, Көньяк, 3 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Ростов, Мелитополь (икесе дә — 1943), Никополь-Криворожск (1944) һәм Варшава-Познань (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 9–23 мартында Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: разведчиклар төркеме б-н Херсон шәһәре тирәсендәге Садовый посёлогы янында елганы кичеп чыга, беренчеләрдән булып дошман траншеясына бәреп керә, блиндажга гранаталар ташлый, автоматтан ут ачып дошманның берничә солдатын юк итә, 13 мартта Херсон шәһәренең көнчыгыш читендәрәк 5 дошман солдатын юк итә. 23 мартта Николаев шәһәреннән 8 *км* көньяктарак алдан баручы күзәтүчеләр составында дошманның алдына чыгып ут ача, берничә солдатны юк итеп, разведка төркеменә уңышлы үтәргә ярдәм итә; 1944 нең 28 июлендә Шерпены торак пунктыннан (Молдавия ССРның Новые Анены р-ны) көньяк-көнбатыштарак булган сугышта дошман урнашкан урынга беренче булып үтеп керә. Граната б-н өч солдатны юк итә, берсен әсир ала, үзе яралана, әмма сафта кала; 1945 нең 28 февралендә Кюстрин шәһәре (Польша, хәзер Костшин ш.) янындагы разведка операциясендә: разведчиклар төркеме б-н, төн караңгылыгыннан файдаланып, дошман окобына яшеренеп үтеп керә һәм пулемётчыны әсир төшерә. 1945 тә демобилизацияләнгәннән соң, туган авылына кайта, колхозда механизатор булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СӨЛӘЙМА́НОВ** Булат (Бикбулат) Вәли улы (28.5.1938, Төмән өлкәсенең Вагай р-ны Супра а. — 5.3.1991, Төмән ш.), шагыйрь. М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1974). Гади эшче була. 1976 елдан Төмән өлкәсендә әдәбиятны пропагандалау бюросы җитәкчесе. Татар вакытлы матбугатында 1960 елларда күренә башлый. 1970 тә аның шигырьләре «Беренче карлыгачлар» исемле күмәк җыентыкка керә. «Таңнар фонтаны» (1980), «Ак метеор» (1988) шигырь җыентыклары авторы. С.ның пейзаж һәм мәхәббәт лирикасы хисле һәм тәэсирле; лирик герое самими, саф күңелле, романтик төсмерләргә бай. Лирик хикәяләр һәм публицистик мәкаләләр авторы. Шигырьләре әзәрбайҗан, кыргыз һәм молдован телләренә тәрҗемә ителә.

Әсәр.: Мин — Себер татарымын. Екатеринбург, 1998.

*Әд.:* Сайфуллина Ф.С. Формирование и развитие татарской литературы тюменского региона. Тюмень, 2007; Писатели Тюменской области: Библиогр. указ. Свердловск, 1988.

**СӨЛӘЙМА́НОВ** Валерий Фиал улы (29.8.1964, Мари АССРның Бәрәңге пос.), астроном, физика-матем. фән. д-ры (2008). 1986 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, Казан Федераль ун-ты Физика ин-тының астрофизика һәм космик геодезия бүлегендә астрофотометрия һәм йолдыз атмосфералары лаб-ясенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре (2009 дан). Хезмәтләре астрофизик объектлар атмосферасында нурланыш күчүгә һәм бу атмосфераларны модельләштерүгә, тыгыз куш системалардагы компактлы объектлар аккреациясен өйрәнүгә карый. Рентген барстерларындагы нейтрон йолдызлар массасын һәм радиусларын билгеләү алымын эшли. Күп кенә ак кәрләләрнең массаларын билгели. Нейтрон йолдыз өслеге б-н кечкенә массалы куш рентген системаларындагы аккреацион диск арасындагы чиктәш катламнарның нурлану спектрларын исәпли.

Хезм.: Угловые диаметры звёзд, полученные из анализа фотоэлектрических покрытий // Письма в Астрон. журн. 1990. Т. 16, № 2 (автордаш); Толщина аккреционных альфа-дисков: теория и наблюдения // Астрон. журн. 2007. Т. 84, № 7 (автордаш); Моделирование атмосфер нейтронных звёзд: от барстеров до магнитаров // Уч. зап. Казан. ун-та. Сер. Физ.-матем. науки. 2011. Т. 153, № 2; RXTE broadband X-ray spectra of intermediate polars and white dwarf mass estimates // Astronomy and Astrophisics. 2005. V. 435 (автордаш); A Neutron Star Stiff Equation of State Derived from Cooling Phases of the X-Ray Burster 4U 1724–307 // Astrophysical Journal. 2011. V. 742 (автордаш).

**СӨЛӘЙМА́НОВ** Габделвахид (1786, Түбән Новгород губ. Зур Рбишча а., башка мәгълүматлар буенча, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Әпсәләм а. — 4.8.1862, Уфа ш.), дин эшлеклесе. Каргалы бистәсе мәдрәсәсендә укый (Оренбург губ.). 1822 елдан С.-Петербургта имам-хатиб, бер үк вакытта, 1828 дән, Кавказ ярымэскадронында ислам кагыйдәләрен укыта, 1835 тән Царское Селодагы кадетлар корпусында. 1832 дә *тархан* титулы ала. 1826 да Россия хөкүмәте тарафыннан Олы һәм Урта казакъ җүзләре ханнары б-н сөйләшүләр алып баруга җәлеп ителә; Эчке эшләр министрлыгында Руханилык эшләре департаментының штаттан тыш тылмачы була. 1840 тан Оренбург Дини Мөхәммәди канун Җыены мөфтие, бер үк вакытта, 1856 дан, Оренбург губернасы попечительләр ком-тының төрмәләр буенча директоры. Утырышчыларның вәкаләтләрен чикләү максатында, Диния нәзарәтен үзгәртеп кору өчен берничә проект төзи (тормышка ашырылмый). Мөселман уку йортларында дөньяви фәннәр укыту яклы була. Шәригатьчә никах-гаилә хокукларын һәм Россия кануннары нормаларының уңышлы синтез үрнәге булган «Гаилә-никах мөнәсәбәтләре кагыйдәләре»н әзерли һәм бастырып чыгара.

*Әд.:* Сенюткина О.Н. Габдулвахид б. Сулейман б.Салюк: К 220-летию со дня рождения. Н.Новгород, 2006; Хабутдинов А.Ю. Российские муфтии: от екатерининских орлов до ядерной эпохи (1788–1950). Н.Новгород, 2006.

**СӨЛӘЙМА́НОВ** Җәүдәт Шәүкәт улы (15.3.1955, Чуаш АССРның Батыр р-ны Кызыл Чишмә а.), информатика өлкәсе галиме, татар телен компьютерлаштыру белгече, язучы, техник фән. д-ры (2000), ТР ФА академигы (2007; 2004 елдан — мөхбир әгъзасы), 2011–2015 тә вице-президенты. ТРның атказ. фән эшлеклесе (2012). 1977 дә Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук, теоретик кибернетика кафедрасында эшли, бер үк вакытта, 1990–96 да ясалма интеллект лаб-ясе, 2000 нән Казан ун-тының компьютер лингвистикасы лаб-ясе җитәкчесе, проф. (2003), 2009 дан ТР ФАнең «Гамәли семиотика» фәнни-тикшеренү ин-ты директоры, социаль-икътисад фәннәре бүлегенең акад.-секретаре (2012 дән). Татар теле морфологиясенең компьютер моделен эшли. Татар телендә эш башкару, нәшер итү, укыту өчен компьютер системаларына татар телендә программа комплекслары булдыра. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009). 1994 тән аеруча сәләтле балаларга ярдәм итү б-н шөгыльләнүче «Сәләт» яшьләр иҗтимагый хәрәкәтен җитәкли. ТРның Җәмәгать Палатасы (2006–08) һәм ТРның Язучылар берлеге (2001 дән) әгъзасы.

Татар телендә «Ямаулыклар» (1995), «Күләгәләр» (1997), «Мин минсез дөньяда» (1999), «Кизләү» (2000), «Казык» (2002), «Нәфес» (2007), «Сүтелә йомгак...» (2011), «Вакыт касәсе: поэма һәм шигырьләр» (2014), рус телендә «Фиолетовый дзэн» (2002) шигырь җыентыклары авторы. М.Җәлил исем. респ-ка (2003) һәм ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. (2015) бүләкләре лауреаты. Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Семантический анализ в вопросно-ответных системах. К., 1990 (автордаш); Структурно-функциональная компьютерная модель татарских морфем. К., 2003 (автордаш); Мышление, интеллект, одарённость: вопросы теории и технологии. К., 2005 (автордаш); Термины информатики и информационных технологий: Англо-татарско-русский толковый словарь. К., 2006 (автордаш).



Ж.Ш. Сөләйманов.

**СӨЛӘЙМА́НОВ** Исмәгыйль Һади улы (8.8.1904, Уфа губ., Бәләбәй өязе Иске Бәшир а. — 21.10.1973, Казан), биолог, үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (1965), проф. (1967). Казан ун-тын тәмамлый (1938), шунда ук эшли: үсемлекләр физиологиясе каф. мөдире (1971 дән). Хезмәтләре үсемлекләрнең су режимына һәм аларның суыкка чыдамлылыгын өйрәнүгә карый. С. үсемлекләрдә су халәтен һәм протоплазма компонентларының (аксым һәм липидлар) структур-метаболик үзлекләрен өйрәнү өчен, беренчеләрдән булып физик алымнар (ЯМР, ЭПР, ультратавыш һ.б.) куллана. Аксымнар гидратлашуның күзәнәк эче тирәлегенең оксидлашу-кайтарылу шартларына бәйлелеге һәм ферментлар активлыгы өчен суның әһәмияте турында күзаллауны нигезли. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Мәгариф өлкәсендәге хезмәтләре өчен «Хезмәттәге югары уңышлары өчен» билгесе б-н бүләкләнә.

Хезм.: Физиология покоя и роста красного клевера. К., 1961; Структурно-физические свойства протоплазмы и её компонентов в связи с проблемой морозоустойчивости культурных растений. К., 1964; Состояние и роль воды в растении. К., 1974.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Библиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**СӨЛӘЙМА́НОВ** Наил Морат улы (31.7.1950, Чистай ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2008). 1972 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1973 тән РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2004 тән). Хезмәтләре магнит резонансына һәм аны куллануга; магнит күренешләре, металллар, ярымүткәргечләр һәм металл-водород кушылмалар физикасына карый. С. нуленче магнит кырында мюон спин кайтавазы эффектын теоретик фаразлый һәм тәҗрибәдә таба.

ЭПР күренешенә нигезләнгән металл-водород системалар халәтенең фазалар диаграммасын өйрәнү алымын эшли. Югары темп-ралы ярымүткәргечләрнең юка катламнарында ионлы имплантация юлы б-н пиннинг магнит үзәкләре булдыру методикасын тәкъдим итә. Углерод нанокөпшәләр һәм металл нанокисәкчәләр нигезендә ягулык элементларында һәм водород контейнерларында куллану өчен композитлар табуның физик-химик алымнарын нигезли.

Хезм.: Применение углеродных наноструктурных материалов в топливных элементах // Альтернативная энергетика и экология. 2006. № 8 (автордаш); Новые технологии и научно-технические





Г.Н. Сөләйманова. Ф.З. Сөләйманова.

разработки на пути к водородной энергетике // Энергетика Татарстана. 2007. № 1 (автордаш); Zero-field muon spin echo // Physica B. 2000. V.289–290 (автордаш).

**СӨЛӘЙМА́НОВ** Рамил Фаил улы (1.1.1958, Үзбәкстан ССРның Әндиҗан өлкәсе Ханабад ш.), психолог, психол. фән. д-ры (2005). Түбән Кама музыка уч-щесен (1978), Казан консерваториясен тәмамлый (1986). 1978 дән Апас авылы һәм Яшел Үзән шәһәре музыка мәктәбендә, 1995 тән Яшел Үзәннең 7 нче мәктәбендә педагог-психолог һәм директор урынбасары, 2000 нән Казан соц.-юридик ин-тының Яшел Үзән ф-лында укыта. 2001 дән Икътисад, идарә итү һәм хокук ин-тында (Казан), 2006 дан гомуми психол. каф. мөдире. Хезмәтләре проф. башкару эшчәнлеге һәм проф. музыкант-инструменталист осталыгы психологиясе проблемаларына карый.

Х е з м.: Как научиться читать с листа музыкальные произведения. К., 1999; Психологические основы профессионального мастерства музыканта-инструменталиста. СПб., 2003.

**СӨЛӘЙМА́НОВ** Ренарт Вафа улы (27.7.1937, Уфа ш.), спортчы, тренер (пуля б-н ату), СССРның атказ. спорт остасы (1968), СССРның атказ. тренеры (1984), халыкара категорияле судья (1990), физика-матем. фән. канд. (1966). Башкорт ун-тын тәмамлый (1960). «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Уфа), тренеры А.А.Мироненко. 1966–78 дә Армия үзәк спорт клубы өчен чыгыш ясый (Мәскәү). СССР (1958, 1961–65, 1967–69), Европа (1959, 1963, 1969), дөнья (1970, кече калибрлы пистолеттан атуда; 1962, 1966, 1970, команда зачётында) чемпионы; Европа (1965), дөнья (1970) чемпионатларында көмеш медаль ала, Европа (1965, 1969), дөнья (1966), Олимпия уеннарында (1968) бронза медаль ала. 1976 дан СССР, Россия җыелма командаларында тренер, өлкән тренер. Халыкара ату спорты берлегенең башкарма ком-ты әгъзасы, дөнья чемпионатында (1974, Швейцария), Олимпия уеннарында (1976) техник делегат.

**СӨЛӘЙМА́НОВ** Рушан Габделхак улы (1.1.1957, Горький өлкәсенең Пилнә р-ны Сафаҗай а.), хирург, мед. фән. д-ры (1999), проф. (2000). Горький мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1979), Новгород үзәк район һәм өлкә хастаханәләрендә эшли. 1990 елдан Новгород өлкә хастаханәсендә торакаль хирургия бүлеге мөдире. 2000 нән Новгород ун-тында, 2003 тән госпиталь хирургиясе каф. мөдире. Хезмәтләре күкрәк, үңәч һәм трахея җәрәхәтләре, терәк-хәрәкәт системасы авырулары очрагында хирургик ярдәм күрсәтүгә карый. Уйлап табуга 6 патенты бар. Медаль һәм РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Хирургическая тактика при лечении сочетанных повреждений груди и опорно-двигательной системы. Л., 1987; Повреждения и спонтанные разрывы грудного отдела пищевода // Хирургия. 1999. № 2; Пиопневмоторакс — как осложнение повреждения пищевода // Клиническая медицина. 2003. Т. 9, ч.2.

**СӨЛӘЙМА́НОВА** Гөлсем (Өммегөлсем) Нурмөхәммәт кызы (12.2.1907, Казан — 14.6.1968, шунда ук), җырчы, ТАССРның халык артисты (1957). 1918 елдан әдәби-муз. кичәләрдә беренче укытучысы С.*Габәши* җитәкчелегендәге хорда солист буларак чыгышлар ясый. 1927 дә Казан музыка техникумын тәмамлый. Татар акад. театры спектакльләрендәге җырларны башкара, концертларда катнаша. 1927–58 дә Татар радиосы солисты була, ш.у. Бөтенсоюз радиосыннан да чыгышлар ясый, шул сәбәпле аның иҗаты тыңлаучыларның киң даирәсенә барып ирешә. Мәскәү, Ташкент, Уфа һәм СССРның башка шәһәрләре буйлап гастрольләрдә йөри. С.ның репертуарын татар, башкорт халык җырлары, татар композиторларының җырлары һәм романслары тәшкил итә. Җырчы иҗатына лиризм, ихласлык, шигърилек, төгәл интонация хас. Халык җырларын үтемле башкаруы б-н гомумхалык мәхәббәтен яулый. Искиткеч муз. хәтергә ия, кабатланмас киң диапазондагы калын түбән тембрлы тавышы бигрәк тә халык вокаль традицияләренә охшаш яңгырашлы була. С. репертуарына үзе җыйган һәм яздырган 500 гә якын халык көе, ш.у. С.Габәши, С.Сәйдәшев, М.Мозаффаров, Җ.Фәйзи, З.Хәбибуллин, А.Ключарёв һ.б. татар композиторларының әсәрләре керә. Аның башкаруында «Салкын чишмә», «Күбәләгем», «Батыр егет», «Гөлҗамал» кебек халык җырлары; С.Сәйдәшевнең муз. драмаларыннан Гөлйөзем ариясе («Наёмщик»), Рәйсә җыры («Күзләр») һ.б. аеруча зур уңыш казана. Төрле халыкларның җырларын, Көнбатыш Европа, рус һәм хәзерге заман композиторларының җырларын һәм романсларын татар телендә башкара. Бөтенсоюз радиофестивале лауреаты (1936). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х ө с н и Ф. Гөлсем Сөләйманова // Совет әдәбияты. 1945. № 1; З ә й н а ш е в а Г. Гөлсем Сөләйманова. К., 1957; С ә й ф у л л и н Р. Җырлары белән халыкны юатты // Халыкка багышланган тормыш. К., 2012; Народные артисты. К., 1980.

*Ф.Ш.Салитова.*

**СӨЛӘЙМА́НОВА** Саҗидә Гаделша кызы (3.10.1926, БРның Яңавыл р-ны Югары Тәтешле а. — 10.5.1980, Әлмәт ш.), шагыйрә, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1980). Башкортстан пед. ин-тын тәмамлагач (1950), Башкортстан һәм Татарстанның урта мәктәпләрендә эшли. 1955 елдан Әлмәттә яши, нефть техникумында укыта (1973 кә кадәр), КПССның шәһәр ком-тында лектор, шәһәр радиосында мөхәррир. Шигырьләре матбугатта 1960 еллар башында басыла башлый. «Кыр казлары» (1963), «Юллар, уйлар» (1968), «Фал китабы» (1974; русчага тәрҗемәсе «Предсказание», М., 1977), «Кызыл каурыйлар» (1976), «Сабыр канатлары» (1981), «Тормыш, исәнме!» (1998), русчага тәрҗемәдә «Со звёздами наедине» (2006) исемле шигырь җыентыклары авторы. Башлангыч чор иҗатында С. күбрәк фольклор мотивларына, җырларга таяна, лирик геройның күңел кичерешләрен нечкәлекләре б-н чагылдырырга тырыша. Аның шигырьләренә язылган «Туй җыры» (Ш.Кашапов көе), «Урсал тауда» (Р.Нәгыймов көе) кебек җырлар халык арасында киң тарала. Соңгы чор иҗатында исә метафора өстенлек итә, милли фольклорга хас символик элементлар язма-әдәби сурәтләү чаралары б-н үрелеп килә, дөньяга фәлсәфи караш көчәя, ритмикага байый. «Фал китабы» (1972), «Мәңгелек ут» (1974), «Ак чәчәкле болын» (1976), «Сузган ике кулым» (1977) поэмаларына лирик, эпик-драматик башлангычларның үзара кушылуы хас. С.ның соңгы әсәре — автобиографик характердагы «Гөлбадран» (1980; рус теленә тәрҗемәсе «Дикая рябина», М., 1986) повесте. Әлмәттә С.га бюст куела (2006), шәһәр музеенда экспозиция багышлана, Әлмәттәге урамнарның берсенә аның исеме бирелә.

*Әд.:* М а л и к о в Ә. Гомер мизгелләре: Саҗидә истәлегенә. К., 2001; С ә й ф у л л и н а Ф. Шигъри сүзнең сихри көче: Шагыйрә Саҗидә Сөләйманова иҗаты. Тобольск, 2001.

*Г.М.Габделхакова.*

**СӨЛӘЙМА́НОВА** Флүрә Зыятдин кызы (10.3.1939, Кама Тамагы р-ны Иске Барыш а.), җырчы, ТРның халык артисты (2006). Иҗат эшчәнлеген Казанның М.Горький исем. мәдәният йортында татар халык хорында башлый, хорның җитәкчесе С.*Садыйкова* аңа проф. башкаручы булырга тәкъдим итә. 1960 елдан Казакъстан ССРның концерт оешмаларында, 1962–65 тә Ульянов филармониясендә солист. 1967–71 дә ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение ком-тында эшли, 1971–91 дә Татар филармониясе солисты. Татарстан композиторларының җырларын (Җ.Фәйзи, Р.Яхин, Ә.Бакиров, Ф.Әхмәтов, М.Макаров, Ф.Әхмәдиев, Ф.Хатыйпов, Р.Гатауллин һ.б.) һәм татар халык җырларын башкаручы буларак киң танылу ала. Йомшак тембрлы моңлы тавышка ия. Җырчы репертуарында борынгы озын көйләр аерым урын алып тора. Соло концерт программалары арасында «Һаман истә» (1999), «Милли сандугач» (2004), «Җырлап үтсен әле гомерләр» (2009) һ.б. бар. Радио һәм телевидениедә чыгышлар ясый. Грампластинкаларга языла (1970, 1974, 1976 һ.б.). Үзе башкаруында 90 җыр язмасы б-н СД-диск чыгара (2009; тууына 70 ел тулу уңаена туры китереп).

*Әд.:* Ә х т ә м о в а Р. Таулар текә, су тирән, тирән булса да керәм... // Сөембикә. 1999. № 4; Й о с ы п о в а Р. Күңел ярасына дәва табасы... // Сәхнә. 2006. № 2; К 70-летию Ф.Сулеймановой // Татарстан. 2009. № 2.

**«СӨЛӘЙНЕ́ФТЬ»**, к. «*Җәлилнефть*».

**СӨЛӘНГЕ́Р КУЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Вятка увалы калкулыгының көньяк өлешендә, Питиал елгасы бассейнының уңъяк яр

өлешендә, Биектау р-ны Мәмдәл авылыннан 2 *км* төньяктарак урнашкан. Су өслегенең мәйданы 1,2 *га*. Су күләме якынча 24 мең *м*³. Озынлыгы 250 *м*, киңлеге 110 *м*. Уртача тирәнлеге якынча 2 *м*, иң зур тирәнлеге 11 *м*. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә хасил булган. Калаксыман, катлаулы формада; 2 плёсы бар. Туенуы катнаш: атм. явым-төшемнәре һәм грунт сулары исәбенә. Суы гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта, бик йомшак, җиңелчә минеральләшкән. Үтә күренмәлелеге 50 *см*. Ял итү максатларында файдаланыла.

**СӨЛГЕ́**. Татарларда элек-электән гамәли максатларда йортны (почмаклар, тәрәзәләр, ишекләр, көзгеләрне һ.б.) бизәү өчен, традицион халык бәйрәмнәренең (Җыен, *Сабан туе* һ.б.), туу, үлгән кешене искә алу һәм туй йолаларының мәҗбүри атрибуты буларак кулланыла. С. өчен, гадәттә, кулдан тукылган, соңрак ф-када җитештерелгән киҗе-мамык (сирәк кенә ефәк) тукыма файдаланыла. Кулдан тукылган С. башлары, гадәттә, чигеп бизәлә, кайчак аларга (ешрак керәшен татарларда) бәйләнгән челтәр тегеп куела. Тукылган С.дәге бизәкләр аралашып килгән горизонталь буйлар (бер киң һәм 2–4 таррак) яисә челтәрсыман композиция рәвешендә урнашалар, киртләчле-киртләчле вак геом. фигуралар, аралары вак бизәкләр б-н тутырылган X- һәм S-сыман һ.б. рәсемнәрнең мотивлары кушылмасыннан торалар (к. *Сәнгати туку*). Бизәкләр төшерү өчен салават күперенең, карадан кала, барлык төсләре кулланыла. Чүпләмле С.ләр ике төстә, ешрак кызыллы-аклы була. Пермь татарларында һәм Сергач мишәрләрендә С.нең төп өлеше алача ысулы б-н тукыла, баш-башлары бизәкләп эшләнә. Чигүле С. башларын бизәкләү, гадәттә, чәчәк-үсемлек рәсемнәре б-н еш кына элмәләп чигү, ш.у. нагыш чигү, элмәкләп яки күпертеп чигү (к. *Чигү*) һәм укалап чигү техникасында башкарыла. Борынгы С.ләргә үсемлек-чәчәк мотивларыннан (лалә, лотос, күгәрчен күзе, канәфер, роза, кыңгырау һ.б.), ш.у. парлы кошларның (күбрәк күгәрченнәрнең), күбәләкләр, балыкларның һ.б.ның шартлы сурәтләреннән торган бер киң һәм ике тар кайма рәвешендәге бизәкләр төшерелә.

20 йөз уртасына кадәр чигүле С.ләр татар йорты интерьерын бизәү өчен кулланыла, аларны бүлмәләр арасындагы такта бүлгегә (исарчык), тәрәзәләр арасындагы диварларга, бүлмә почмакларына эләләр. С. яучылау, туй вакытында (к. *Казан сөлгесе*), туу һәм җирләү ритуалларында, бәйрәмнәрдә (ат дугаларын, мәйданнардагы колгаларны һ.б. бизиләр), ш.у. Сабан туе бәйрәмендә җиңүчеләргә бүләк ителә.

20 йөз башында, ф-када җитештерелгән арзанлы тукымалар таралыш алу сәбәпле, традицион С.ләр әкренләп татарларның көнкүрешеннән югала бара. Аерым авылларда иң гади бизәк б-н тукылган С.ләр 20 йөз уртасына кадәр эшләнә. Бүләк һәм сувенир буларак, чигүле, ш.и. проф. рәссамнар эскизлары буенча укалап чигелгән С.ләр «Туран» милли-мәдәни үзәге фонды, Казан өйдә эшләүчеләр комбинаты остаханәләре, тукылган С.ләр — Алексеев туку ф-касы тарафыннан җитештерелә. Күргәзмәгә кую өчен уникаль С. үрнәкләрен Казан осталары С.Кузьминых, Л.Фәсхетдинова, Р.Гыймранова, А.Кудряшова, А.Липина, О.Марсова, Ф.Калмурзина һ.б. иҗат итә. Борынгы С. үрнәкләре Россия этнография музеенда (С.-Петербург), ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда һ.б. саклана.

*Әд.:* Сысоева Н.И. Касимовское узорное ткачество в XIX — начале XX вв. М., 1963; Сафина Ф.Ш. Ткачество татар Поволжья и Урала (конец XIX — начало XX вв.). К., 1996; Валеев Ф.Х. Татарский народный орнамент. К., 2002; Изделия народных художественных промыслов и декоративно-прикладного искусства Республики Татарстан: Каталог. К., 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*





1. Сөлге. Киндер тукыма. Ефәк җеп. Элмәләп чигү. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы; 2. Сөлге. Фрагмент. Киҗе-мамык тукыма, ефәк җеп. Нагыш. 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТР Милли музее.

**СӨЛЕ́К** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 19 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Минзәлә елгасы буенда. 2010 елда 221 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1731 елга кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.тә мәчет, мәктәп, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2198,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Нөркәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Сарман р-нында. Халык саны: 1816 да — 87 ир-ат; 1834 тә — 265, 1859 да — 255, 1870 тә — 640, 1897 дә — 574, 1920 дә — 780, 1926 да — 405, 1938 дә — 610, 1949 да — 421, 1958 дә — 303, 1970 тә — 426, 1979 да — 391, 1989 да — 206, 2002 дә — 226 кеше.

**СӨЛЕ́К УРМАНЫ́**, табигать саклаулыгы. Сарман р-ны Сөлек авылыннан төньяк-көнбатыштарак урнашкан. Минзәлә һәм Игәнә елгалары арасындагы урман участогы (Азнакай урманчылыгының Сарман участок урманчылыгы). 1994 елда билгеләнә. Мәйданы 194,6 *га*. 1 нче яруста имән һәм юкә, 2 нче яруста карама һәм усактан торучы киң яфраклы урман. Нарат һәм чыршы утыртмалары кулдан утыртылган. Куаклыкта сөялле кабар агачы, гади миләш, кызыл аю баланы, гади гөлҗимеш, тал үсә. Үлән капламында 50 дән артык төр, сирәк үсемлекләрдән — ике яфраклы төнге миләүшә һ.б. Хайваннар дөньясы бай (кәҗәболан, бурсык, поши, бүре, төлке, үр куяны); кошлардан — урман тургае, гади соры чыпчыгы, шәүлегән, сандугач, чинар чыпчыгы, көртлек, божыр, суер яши. ТРның Кызыл китабына кертелгән сирәк төрләр: балыкчы карчыга, ак ябалак, байгыш, сакаллы ябалак очрый.



Сөлек урманы.

**СӨЛЕКЛӘ́Р** (Hirudinea), божралы суалчаннар классы. 400 гә якын, Европада 34, Татарстан терр-ясендә 10 га якын төре билгеле, төче суларда яшиләр. Гәүдәсенең озынлыгы 1,5 тән (әкәм-төкәмсыман сөлек) 30 *см* га (медицина сөлеге) кадәр, сырт-корсак юнәлешендә кысылган, корсак ягы яссы, сырты — кабарынкы. Коңгырт тимгелле яшькелт-коңгырт, зәйтүнсыман-яшел төстә. Гәүдәсенең алгы һәм арткы очларында имгечләр — субстратка яки үзенең корбаны гәүдәсенә берегү органнары бар. Алгы имгечләр үзәгендә авыз куышлыгы урнашкан, алар исә алга таба чыгучы хортумчыклы (хортумлы С.) яки казналыклы (казналыклы С.). С. — гермафродитлар, күкәйләрен кузыда салалар. Татарстан терр-ясендә хортумлы С.дән кече ялган кузылы С. (Erpobdella octoculata), әкәм-төкәмсы-



Медицина сөлеге.

ман С. (Glossiphonia complanata), ике күзле (Helobdella stagnalis) һәм балыксыман С. (Piscicola geometra) таралган. С. — күбесенчә ерткычлар, умырткасызлар, чукмарбашлар һәм балыклар б-н туена. Балыксыман С. — балыклар паразиты. Гади кош сөлеге (Protoclepsis tessulata) су кошларының авыз куышлыгында, сулыш юлларында яки күзләренең конъюктив капчыгында паразитлык итә. Зур имезүче хайваннарның һәм кешеләрнең тире капламын кисәргә сәләтле С. ТР терр-ясендә юк. Кан суыру өчен медицинада файдаланылучы медицина сөлеге (Hirudo medicinalis) көньяктарак таралган. Ул лаб. шартларында үстерелә. Аларда барлыкка килүче гирудин матдәсе дәвалау эффекты бирә. Гирудин матдәсе канга эләгеп, гипертония, тромбофлебит һ.б. авырулар вакытында кеше организмына уңай тәэсир ясый.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1969. Т. 1; Лукин Е.И. Пиявки пресных и солоноватых вод. Л., 1976; Райков Б.Е., Римский-Корсаков М.Н. Зоологические экскурсии. М., 1994.

*В.А.Яковлев.*

**СӨЛЧӘ́** елгасы, Идел алдында, Зөя елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 43,1 *км*, бассейнының мәйданы 548 *км*$^2$. Идел буе калкулыгыннан, Югары Ослан р-нында ага. Елга башы Мәйдан авылыннан 3 *км* көнбатыштарак, тамагы Савино авылыннан төньяктарак. Елганың түбән агымы Куйбышев сусаклагычының терәү сулары астында калган. Зөя кебек, элек С.дә Идел кушылдыгы булган (ул вакытта Зөя тамагы хәзерге Зөя утравының көнбатышында урнашкан була). *Голоцен* чоры башында Зөя акрынлап уңга күчә һәм С. үзәненең тамак өлешен били, ул исә Зөя елгасының кушылдыгы булып кала. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. Су җыелу мәйданы көньяктан төньякка авыш калкулыклы асимметрияле



Сөлчә елгасы.
Югары Ослан районы Куралово авылы янында.

тигезлектән гыйбарәт; аның сулъяк яр өлеше шактый зуррак. Үзәне асимметрияле, аның уңъяк сөзәклеге текәрәк һәм күтәренке, күп кенә урыннарда ерым, сыза, уйсулыклар б-н ергаланган. С.нең уңъяк яры өчен карст нәтиҗәсендә барлыкка килгән упкын һәм шуышмалар хас. Елга юлы бормалы, тармакланмаган, киңлеге 5–6 *м*. Елга агымының тизлеге 0,1–0,2 *м/с*. Суының иң аз вакытындагы тирәнлеге 0,4–1 *м*. С.нең 17 кушылдыгы бар, иң зурлары: Чангар (14,4 *км*), Келәнче (15,1 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,4 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, абс. күпчелек кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 113 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана, апрельнең беренче ункөнлегендә иң югары дәрәҗәсенә җитә. Суның биеклеге күтәрелгәндәге кебек үк, тиз кими. Җәйге челләдә су биеклеге тотрыклы саклана, түбән, яңгырлар артык тәэсир итми. Куралово авылы янында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,22 *м*$^3$*/с*. Кышкы челлә боз катканнан соң башлана, су биеклеге тотрыклы. Боз катуның уртача дәвамлылыгы 130 көн. Елга җир асты сулары чыккан яки агым көчле булган урыннарда кыш дәвамында диярлек боз б-н капланмый. Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта, язын уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. С. бассейнында суының гомуми күләме 1,1 млн. *м*$^3$ булган 4 буа бар. Су ресурслары сугару өчен һәм сәнәгый җитештерүдә (Куралово авылындагы крахмал җитештерү комбинаты) файдаланыла. ТРның табигать истәлеге (1978).

*О.Н.Урбанова.*

**СӨЛЧӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Олы Сөлчә елгасының (Олы Чирмешән елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 21,5 *км*, бассейнының мәйданы 117,5 *км*$^2$. Идел аръягы түбәнлеге буйлап ага. Елга башы урман массивында Чирмешән р-ны Кызыл Чишмә авылыннан 2 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы — Аксубай р-ны Иске Кызылы авылында. Елга башының абс. биеклеге 190 *м*, тамагыныкы — 101 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. С.нең 0,5 тән 4,8 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 104 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,056 *м*$^3$*/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. С. бассейнында суының гомуми күләме 2 млн. *м*$^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**СӨЛЧӘ́** (Карамыш) елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Олы Кәминкә елгасының (Чишмә елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 16,4 *км*, бассейнының мәйданы 147,7 *км*$^2$. Чирмешән р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы урман массивында, Ивашкино авылыннан 2,5 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Түбән Кәминкә авылыннан 5 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 168 *м*, тамагыныкы — 78 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. С.нең 2 кушылдыгы бар, иң зурысы: Күтәмә елгасы (13,5 *км*) — уң кушылдык. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,32 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, өчтән ике өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,51–1 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 111 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,208 *м*$^3$*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада суының гомуми күләме 2,3 млн. *м*$^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**СӨЛЧӘБА́Ш** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 26 *км* көньяктарак, Кече Сөлчә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 74 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1926 да нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Күтәмә волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1940 ның 7 октябреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1949 да — 250, 1958 дә — 279, 1970 тә — 249, 1979 да — 160, 1989 да — 66, 2002 дә — 88 кеше.

**СӨН** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Агыйдел елгасының (Кама елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 196,6 *км*, бассейнының мәйданы 4500 *км*$^2$. Елга башы, югары һәм урта агымы, тамак алды өлеше Башкортстан терр-ясендә, 67,2 *км* озынлыктагы түбән агымы Актаныш р-ны терр-ясендә һәм БР чиге буйлап ага. Елга башының абс. биеклеге 220 *м*, тамагыныкы — 62 *м*. С.нең су җыелу мәйданының шактый өлеше Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгы чикләрендә урнашкан. Субүләрләрнең өстенлек итүче биеклеге — 160–170 *м* (макс. 267 *м*). С. бассейны терр-ясе югары Пермь, неоген һәм дүртенчел чор яшендәге утырма токымнарның калын катламыннан тора; ерым һәм сызалар челтәре б-н ергаланган. ТР чикләрендә су җыелу мәйданының урманлылыгы якынча 5%. Урман үсемлекләре, нигездә, зур булмаган участокларда үсә; өстенлек итүче токымнар — имән, каен, усак. С.нең үзәне асимметрияле, түбән агымында 4–5 *км* га кадәр. Сөзәклекләр террасалардан тора. Уңъяк сөзәклеге текә, сул ягы — авышрак, салмак кына субүләргә күчә. Тугае ике яклы, киң, күп кенә урыннарда таллар һәм төрле үләннәр үскән. Елга юлы бормалы, тармакланмаган, 30–40 *м* киңлектә. Тирәнлеге перекатларда 0,5–0,7 *м* дан плёсларда 2 *м* га кадәр һәм күбрәк тә. Агым тизлеге 0,5–0,7 *м/с*, 67 кушылдыгы бар, ТРдагы иң зурлары: Калмыя (37,2 *км*), Сикия (27,3 *км*), Терпеле (23,8 *км*), Бичады

(22,5 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,66 *км/км*$^2$.

Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Елга режимын күзәтүләр ТР терр-ясендә Актаныш р-ны Меңнәр авылы янындагы су үлчәгеч постта алып барыла (1941 дән). Ел фасыллары буенча агымның бүленеше тигез түгел. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 92–120 *мм*, ташу агымы катламы 60–80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана һәм бу вакытта елгада су биеклеге бик тиз күтәрелә. Су биеклегенең уртача еллык тирбәнеше 4,5 *м* (макс. — 7,2 *м*, 1957); макс. су чыгымы 805 *м*$^3$*/с* (1950), 655 *м*$^3$*/с* (1979). Ташу уртача 44 көн дәвам итә. Җәен су биеклеге тотрыклы саклана. Яңгыр ташуларының йогынтысы зур түгел. Ташу агымының уртача күпьеллык катламы 3,1 *мм*, уртача 12 көн дәвам итә. Суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы: тамагында — 3,76 *м*$^3$*/с*, Меңнәр авылы янында — 3,6 *м*$^3$*/с*. Боз күренә башлау б-н, кышкы четтә башлана. С., гадәттә, ноябрь башында туңа. Боз катуның уртача дәвамлылыгы — 155 көн. Кыш ахырына бозның калынлыгы 60–70 *см* га җитә, макс. калынлыгы — 97 *см* (1969). Суы гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта, язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 700 *мг/л* дан артык. С. бассейнында ТР терр-ясендә суының гомуми күләме 4,1 млн. *м*$^3$ булган 5 буа бар. Су ресурслары сугару һәм а.х. пр-тиеләрен су б-н тәэмин итү өчен файдаланыла. ТРның табигать истәлеге (1978). С.ның яр буе зонасында күп кенә кошлар, ш.и. ТРның Кызыл китабына кертелгән зур күлбога, кече күлбога, соры көртлек, соры торна, су тавыгы, үлән шөлдие, зур шөлди, соры сорокопут оялый.

*О.Н.Урбанова.*

**СӨНӘГАТУ́ЛЛИН** (Сөнгатуллин) Фарук Әхмәдулла улы (27.8.1946, Чиләбе өлкәсенең Сосновка р-ны Әсән а.), вет. хирургы, фармаколог, биол. фән. д-ры (1999), проф. (2003). Троицк вет. ин-тын тәмамлый (1968). 1970–76 елларда Чиләбе өлкәсе Пласт р-нында вет. табибе булып эшли. 1974–2005 тә Троицк вет. ин-тының акушерлык һәм клиник диагностика кафедрасында, проф. (1996 дан), каф. мөдире (2003 тән). 2005 тән Казан вет. медицинасы академиясендә, проф. (2005 тән), вет. хирургиясе каф. мөдире (2009 дан). Хезмәтләре вет. хирургиясе мәсьәләләренә, терлек авыруларын дәвалау һәм кисәтүдә табигый чаралардан файдалануга карый. Уйлап табуга 30 патенты бар.

Х е з м.: Фармакотоксикологические свойства эраконда и его применение в ветеринарии. Троицк, 2004 (автордаш); Биологически активные добавки при транспортном стрессе. М., 2005 (автордаш); Новокаиновская терапия в ветеринарии. К., 2013 (автордаш).

**СӨНГАТЗАДӘ́** (псевд., чын фамилиясе Сәйфетдинова-Шаммасова) Хәдичә Сөнгатулла кызы (1875, Сембер губ., хәзер Ульянов өлкәсе Татар Колмаеры а. — 9.5.1949, шунда ук), шагыйрә. Мулла гаиләсеннән. Башлангыч белемне өйдә ала. Туган авылында 2 нче мәхәллә кызларын укыта. Җәдиди мәктәп укытучылары өчен курсларны тәмамлагач, укытуын дәвам итә. «Кызлар бакчасы»(1913), «Таң җиле» (1914) җыентыклары, «Гәүһәр түгел, Морат алданды» исемле басылмаган хикәя авторы. С. иҗаты, автор фикеренчә, надանлык, көнчелек, яңалыкны кабул итмәү кебек тискәре күренешләр сәбәпле артта калган татар милләтенең киләчәге турында кайгыру-хафалану хисе б-н сугарылган. Тәрәккыятьнең төп шартлары дип халыкны укыту-агартуны, әхлак дәрәҗәсен күтәрүне саный. С.нең аерым шигырьләре «Өмет йолдызлары» күмәк җыентыгына кергән (1988).


*Әд.:* Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Библиогр. сүзлек. К., 2005.

**СӨНГАТИ́** (Сөнгатуллин) Габдрахман Фәтхулла улы (10.3.1894, Казан губ., Тәтеш өязе Балчыклы а. — 1917 елдан соң), шагыйрь. Мулла гаиләсеннән. «Халидия» мәдрәсәсендә укый. 1914–15 елларда «Ак юл» ж-лында эшли. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1917 дә сугышта хәбәрсез югала. 1913 тә мәкаләләре басыла башлый. С.нең шигырь, балладалары «Аң», «Сөембикә», «Ак юл» ж-лларында, «Кояш», «Халык» г-таларында дөнья күрә. «Таңгы җырлар» (1915), «Ил фәрештәсе» (1916) һ.б. шигырь җыентыклары авторы. С. иҗатына гражданлык мотивлары, татар милләте язмышын кайгырту, халыкка хезмәт итү теләге хас. Гади солдатның авыр тормышын, уй-кичерешләрен, кан коюның мәгънәсезлеген тасвирлаган хәрби шигырьләр циклы аерым урын алып тора. С. шигырьләре «Татар поэзиясе антологиясе»нә кергән (1956; рус теленә тәрҗемәсе 1957).

*Әд.:* Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Библиогр. сүзлек. К., 2005.

*Ф.И.Ибраһимова.*

**СӨНГАТУ́ЛЛИН** Мирсәет Миншаһит улы (25.7.1953, Әлки р-ны Татар Борнае а.), җырчы (баритон), ТРның халык артисты (1998), РФнең атказ. артисты (2009). 1984 елда Казан консерваториясен (И.Ишбүләков классы) тәмамлый. 1976–77 дә ТАССРның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле хоры артисты, 1984 тән — Татар филармониясе, 1987 дән — Мәскәү өлкә филармониясе (аның тарафыннан оешкан татар «Бәйрәм» ансамбле составында), 1989–91 дә Татар опера һәм балет театрының концерт төркеме солисты. 1991–93 тә «Ватаным Татарстан» г-тасы үзхәбәрчесе, 1993 тән — «Казан» милли мәдәният үзәге каршындагы «Идел егетләре» фольклор ансамбле, 1997–2007 дә — «Идел» концерт-филармония берләшмәсе, 2007 дән Әлки р-ны Мәдәният йортының халык хоры коллективы солисты. Көчле яңгырашлы тавышка ия, башкаруы профессиональлеге һәм югары сәхнә культурасы б-н аерылып тора. С. иҗатында милли вокаль башкару традициясе лаеклы рәвештә үстерелә (аеруча борынгы озын татар көйләрендә). Репертуарын татар халкы җыр мирасының иң яхшы үрнәкләреннән сайлаган 600 дән артык җыр (халык җырлары — «Тәфтиләү», «Әллүки», «Зиләйлүк», «Уел», «Зәңгәр шәл», «Күн авылы көе», «Авыл көе», «Мәк чәчәге», «Сакмар», «Ай янында якты йолдыз», «Бөрлегәнем — бер генәм» һ.б., татар композиторларының җырлары — А.Ключарёвның Г.Зәйнашева шигыренә «Туган җирем — Татарстан», С.Сәйдәшевнең Х.Фәтхуллин шигыренә «Хуш, авылым», Р.Яхинның Ә.Ерикәй шигыренә «Җырланмаган әле безнең җыр», М.Яруллинның Р.Корбан шигыренә «Туган авылым», М.Макаровның Р.Гаташ шигыренә «Язгы ташу», Х.Туфан шигыренә «Юксындырсаң нишләрмен», халык сүзләренә «Тулпар атым» һ.б.); үзе иҗат иткән җырлар (Ф.Сафин шигыренә «Борнаем — туган җирем», Г.Зәйнашева шигыренә «Болгар авылы көе», Б.Рәхимова шигыренә «Туган як», Р.Корбан шигыренә «Чиябаш авылы көе» һ.б.); рус халык җырлары һәм рус композиторлары җырлары тәшкил итә. Россия шәһәрләрендә, Төркия, Финляндия, Үзбәкстан, Казакъстан, Таҗикстан һ.б. күп кенә илләрдә концертлар бирә, радио һәм телевидениедә һәрдаим чыгышлар ясый.



М.М.Сөнгатуллин.

Х е з м.: Җылы бирсен җырым. К., 2001.

**СӨНГАТУ́ЛЛИН** Равил Әмин улы (9.1.1949, Саба р-ны Югары Шытсу а.), зоотехник, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1998). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), Саба р-нында: «Беренче Май» к-зында зоотехник, баш зоотехник (1973 тән), рәис (1976 дан). 2006 елдан Саба р-ның Халык мәшгульлеге үзәге директоры. С. җитәкче булганда, «Беренче Май» к-зында җитештерү, социаль-мәдәният һәм көнкүреш объектлары төзелә. 2005 тә бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 38,6 *ц* га, еллык савым һәр сыердан уртача 4065 *кг* га җитә. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Н ә җ м и е в Т., Ә х м ә т җ а н о в И. Туган туфрак кадере. К., 2003.

**СӨНГАТУ́ЛЛИН** Рафаэль Харис улы (6.11.1962, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (2010). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1985), «Амургеология» ҖБдә (Тында ш.) эшли. 1993 елдан Казанда: «Волгагеология» ҖБдә, «Татарстангеология» АҖдә (2003 тән баш геолог), Казан ун-тында (2009 дан). Хезмәтләре геоэкология, геохимия, литология, гидрогеология, геол. модельләштерүгә карый. ТРның Түбән Кама һәм Чаллы р-ннарының экологик, ТРның төньяк-көнчыгыш өлешендәге су төбе утырымнарының геохимик карталарын төзи; ТР торак пунктларын һәм сәнәгать пр-тиеләрен су б-н тәэмин итүдә җир асты эчәргә яраклы һәм техник сулар запасын исәпли. Уйлап табуга патенты бар.

**СӨНГАТУ́ЛЛИН** Фарук Фатих улы (2.1.1942, Буа р-ны Әхмәт а.), хокук белгече, ТССРның, РФнең атказ. юристы (1991,

1997). Казан ун-тын тәмамлый (1973). 1965–70 елларда Казанның 1 нче автохуҗалыгында эшли. 1970–72 дә Казанның 1 нче йөк автотранспорты пр-тиесендә профсоюз ком-ты рәисе. 1972–73 тә Казанның 2 нче автотранспорт пр-тиесендә бүлек башлыгы. 1973–74 тә Казанның Бауман р-ны прокуроры ярдәмчесе. 1974–76 да ТАССР Прокуратура органнарында прокурор. 1976–87 дә КПССның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы. 1987–88 дә Казан прокуроры. 1988–92 дә ТР Дәүләт арбитражының баш арбитры. 1992–95 тә ТР Югары арбитраж мәхкәмәсе рәисе. 1995–2008 дә Идел буе округы Федераль арбитраж мәхкәмәсе рәисе. Халыклар дуслыгы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

*Е.Б.Долгов.*

**СӨНГАТУ́ЛЛИН** Хәмит Газиз улы (27.7.1940, Казан), архитектор, ТАССРның атказ. архитекторы (1987). 1972 елда Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлаганнан соң, «Татгражданпроект» ин-тында эшли. 1977 дән «Казгражданпроект» ин-тында проектларның баш архитекторы, 1987 дән бүлек башлыгы. 1993–97 дә шәхси иҗат остаханәсе җитәкчесе. Архитекторлар берлеге әгъзасы (1976). Казандагы «Татарстан» кунакханәсе интерьерлары авторы (1968–70, М.Х.Агишев һәм М.Г.Хәйруллин б-н бергә). С. проектлары буенча Казанда ТАССРның Эчке эшләр министрлыгы мәктәбе (1976), Казан финанс-икътисад ин-тының уку-лаб. корпусы һәм уку-торак комплексы (1977–82), «Болгар» кунакханәсе төзелә. 1997 дә Казан Кремлендәге Кол Шәриф мәчете проектына конкурс лауреаты (башка проект буенча төзелә).

**СӨНГАТУ́ЛЛИНА** Зилә Даян кызы (30.7.1949, БАССРның Кыйгы р-ны Югары Кыйгы а.), җырчы (лирик сопрано), педагог, ТАССР, Каракалпак АССР һәм РФнең халык артисты (1980, 1980, 1995). 1973 елда Казан консерваториясен (В.Лазько классы) тәмамлый. 1973 тән Татар опера һәм балет театры солисты. Рус, чит ил һәм татар композиторлары операларында 40 тан артык төп партия башкара: Госпожа Зильберкланг («Театр директоры», В.А.Моцарт), Розина («Севилья чәчтарашы», Дж. Россини), Джильда, Виолетта, Дездемона («Риголетто», «Травиата», «Отелло», Дж. Верди), Норина («Дон Паскуале», Г.Доницетти), Маргарита («Фауст», Ш.Гуно), Микаэла («Кармен», Ж.Бизе), Мими («Богема», Дж. Пуччини), Марфа («Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Татьяна, Иоланта («Евгений Онегин», шул исем. әсәр буенча, П.Чайковский), Кар кызы (шул исем. әсәр буенча, Н.Римский-Корсаков), Тамара («Демон», А.Рубинштейн), Алтынчәч (шул исем. әсәр буенча, Н.Җиһанов), Әлфия («Самат», Х.Вәлиуллин), Галимә («Кара йөзләр», Б.Мөлеков) һ.б. С. көчле, киң диапазонлы, тәэсирле, үзенчәлекле, «көмештәй» тембрлы тавышка, драматик талантка, югары проф. осталыкка ия. Җырчының иҗат диапазоны бик киң һәм ул төрле чордагы, стильдәге һәм жанрдагы әсәрләрне, ш.и. татар халык җырларын («Ал Зәйнәбем», «Сибелә чәчем», «Зөлхиҗә» (башкорт халык җыры), «Олы юлның тузаны», «Дустыма»), татар композиторлары җырларын («Керим әле урманнарга», «Яз чәчәген өзмә минем өчен», Р.Яхин; «Өзелгәнсең сиреньнән», Н.Җиһанов) колачлый. Зур концерт репертуарына ия. 1983 тән Казан консерваториясендә укыта, 1998 дән вокал сәнгате каф. мөдире, проф. (1998). Укучылары арасында халыкара конкурслар лауреатлары, әйдәп баручы опера театрлары солистлары, концерт бирүче башкаручылар һәм педагоглар (А.Шаһиморатова, А.Гобәйдуллина, Пак Тэ Кюн (Көньяк Корея) бар. Актив концерт эшчәнлеге алып бара. Опера спектакльләрендә катнаша, соло концерт программалары б-н Россия шәһәрләрендә, Бөекбритания, Германия, Ирландия, Литва, АКШ, Төркия, Украина, Финляндия, Франция, Чехия, Швейцария һ.б. илләрдә чыгышлар ясый. ТРның күренекле мәдәният эшлеклеләренә, вокал укыту методикасы мәсьәләләренә багышланган басмалары бар. Муз.-иҗтимагый һәм муз.-мәгариф эшчәнлеге алып бара. РФнең Театр эшлеклеләре берлеге (1980), ТРның Иҗтимагый палатасы (2006 дан) әгъзасы. Халыкара, бөтенроссия һәм төбәкара конкурсларда, ш.и. М.Глинка исем. Бөтенроссия конкурсында, Р.Яхин исем. Халыкара камера җырчылары һәм концертмейстерлар конкурсында, Респ-ка «Созвездие — Йолдызлык» эстрада сәнгате телевизион яшьләр фестивалендә, Респ-ка «Җырчы сандугачлар иле», С.Сәйдәшев исем. Төбәкара вокалистлар һәм И.Шакиров исем. Халыкара татар җырын башкаручылар конкурсларында даими рәвештә жюри әгъзасы була. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1984). Халыклар дуслыгы ордены б-н бүләкләнә.



З.Д. Сөнгатуллина.



З.Д. С ө н г а т у л л и н а Розина ролендә («Севилья чәчтарашы», Дж. Россини).



З.Д. С ө н г а т у л л и н а Шагыйрь хатыны ролендә («Муса Җәлил», Н. Җиһанов; Канзафаров ролендә – Р.Ә. Сәхәбиев).

*Әд.:* Х ә й р у л л и н а З. Опера сәнгате йолдызы // Казан утлары. 1999. № 5; Г ә р ә е в М. Баш ия чәчәкләр, Җырлашып каршыңда // Сөембикә. 1999. № 7.

**СӨННӘ́** (гарәп. سنة — юл, үрнәк), *Мөхәммәд* пәйгамбәрнең кылган гамәлләре һәм сөйләгән сүзләре турында хәдисләр бәяны. Исламның барлык агымнары тарафыннан мөселман өммәте һәм һәр мөселман өчен тормышның барча мәсьәләсен хәл иткәндә үрнәк һәм кулланма буларак Коръәннән кала иң нык хөрмәтләнүче мәгълүмат чыганагы. Пәйгамбәрнең сәхабәләре арасында телдән-телгә йөргән һәм *хәдисләр* (сөнниләрдә), әхбарлар (шигыйләрдә) рәвешендә теркәлгән. Мөхәммәд пәйгамбәрнең кылган гамәлләрен (фил), аның әйткән сүзләрен (кауль) һәм хуплавын (тәкърир) тасвирлаудан гыйбарәт. Традицион исламда С.гә иярү мөселманнарның яшәү рәвеше булып санала. С. өйрәнү — мөселман белеменең мөһим өлеше. Коръән кагыйдәләре б-н бергә ул мөселман дини хокукы — *фикъһның* эчтәлеген тәшкил итә. С. белү — *фәкыйһка* (мөселман хокукы белгече) карата төп таләпләрнең берсе. Мөхәммәд пәйгамбәр вафат булганнан соң (632), С. нигезендә гарәп хәлифәлегендәге тормышның гамәли сораулары хәл ителә. 9–10 йөзләргә җиткәндә, хәмбәлиләр С.не Коръән б-н бер дәрәҗәдә хөрмәтли башлыйлар. Хәнәфиләрдә фикъһ чыганагы сыйфатында бернинди искәрмәсез Коръәнне кабул итәләр, ә С., хәдисләрне җентекләп сайлаганнан соң гына, мөстәкыйль чыганак булып санала. Мәликиләр С.не Коръәннең дәвамы итеп карыйлар: пәйгамбәрнең сәхабәләренә — мәдинәлеләргә барып тоташучы хәдисләрне бернинди шәрехләүгә дә юл куелмаган. Хәзерге заман мөселман фундаменталистлары С. буенча яшәүгә зур әһәмият бирәләр, хәтта мөселман кешесенең өс киеме һәм килеш-килбәтенең катгый бер тәртиптә булуын таләп итәләр.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**СӨННӘ́Т**, *ислам* эзеннән баручылар арасында киң таралган сөннәтләү, сөннәткә утырту йоласы. Сөннәткә утырту йоласы исламга кадәр барлыкка килгән; күп кенә халыклар арасында таралуы мәгълүм, мәс. яһүдиләрдә сөннәтләү Аллаһ һәм Израиль халкы арасында килешү символы булып санала. Ис-

ламда мөселманны бүтәннәрдән аера торган билге буларак аңлатыла. *Коръәндә* С. искә алынмый, әмма Сөннәдә үтәргә кушыла, анда Мөхәммәд пәйгамбәрнең үз оныклары Хәсән б-н Хөсәенне тууларының 7 нче көнендә сөннәтләве турында бәян ителә. әл-Бохари һәм Мөслими *хәдисләрендә Ибраһим* пәйгамбәрнең 80 яшендә сөннәтләнүе хәбәр ителә. Сөннәткә утырту яше чикләнмәгән (7 көннән 15 яшькә кадәр мөмкин дип санала). Әлек татарларда сөннәтләүне махсус кешеләр башкарган (баба, бабачы), эшчәнлекнең әлеге төре еш кына мирас булып күчкән. С.кә утырту рев-циягә кадәрге чорда Казан артындагы 2 авылда ир-атлар арасында төп һөнәр булып саналган (Казан губернасындагы Зөя өязенең Кошман һәм Казан өязенең Масра авыллары). Сөннәтче бабалар билгеле бер түләү хакына авыллар буенча үз хезмәтләрен тәкъдим итеп йөргәннәр. С.ләү йоласын дәвалау учреждениеләрендә башкару соңгы еллар яңалыгы булып тора (3 яшьтән).

*Әд.:* Уразманова Р.К. Обряды, связанные с рождением ребёнка // Татары. М., 2001.

**СӨННИЧЕЛЕ́К** (гарәп. — Сөннә әһелләре), *исламда* төп ике юнәлешнең берсе (*шигыйләр мәзһәбе*, шигыйчелек б-н янәшә). 7 йөзнең 2 нче яртысында *Мөхәммәд* пәйгамбәр вафатыннан соң (632), мөселман җәмгыятенең өстенлек итүче хакимият мәсьәләсе буенча таркалуы нәтиҗәсендә барлыкка килә. С. яклылар — сөнниләр шигыйләрнең Галине (Мөхәммәд пәйгамбәрнең этисе б-н бертуган Әбү Талибның улы һәм пәйгамбәрнең кияве) үзгә асыллы санаулары һәм аның мөселман теократик дәүләте б-н идарә итүгә хокукы булуы турындагы карашларын кире кагалар; алар, өстенлек итүче хакимият барлык җәмгыять тарафыннан сайланган хәлифәләр кулында булырга тиеш, дип саныйлар. Соңрак Коръән б-н бергә Мөхәммәд пәйгамбәрнең Сөннәсен, әл-Бохари, Мөслими, әт-Тирмизи, Әбү Дауд, ән-Нисаи, ибн Маҗаһ төзегән *хәдисләрнең* кануни җыентыгының дөреслеген; беренче дүрт хак хәлифә: Әбү Бәкер (632–34), Гомәр бине әл-Хаттаб (634–44), Госман бине Гаффан (644–56), Гали бине Әбү Талиб (656–61) идарәсенең законлы булуын таныганнарны; дүрт *мәзһәбнең* берсенә туры китереп, бердәм дини йолалар, көнкүреш һәм социаль кагыйдәләр буенча яшәүчеләрне сөнниләрдән саный башлыйлар. Илаһият-фикъһ мәктәпләре арасындагы аермалар социаль-икътисади һәм этномәдәни шартлар, хокукый традицияләрнең үзара охшаш булмавы б-н аңлатыла. *Хәнәфиләр* карарлар чыгарганда Коръәнгә һәм Сөннәгә (хәдисләрне җентекләп тикшергән хәлдә), килешенгән уртак фикергә (иҗмагъ), аларда булган өйрәтүләргә охшатып фикер йөртүгә (кыяс), яхшырак күрелгән карарга (истихсан), мөселманнарга кадәрге *гореф-гадәтләргә* һәм йолаларга; мәликиләр бер чыганакка — нәскә берләшкән Коръән һәм Сөннәгә таянганнар (хәдисләрдән тайпылуга юл куелмаган). Кыяс һәм истислах (карарлар җәмгыятьтә файдалы булуларына карап чыгарылган) алымнары киң кулланылган. Хәнәфиләрдә һәм беркадәр кимрәк дәрәҗәдә мәликиләрдә «җәннәт» алымына (төпле акылга нигезләнгән шәхси фикер) өстенлек бирелгән. Хәнәфиләр һәм мәликиләрнең көчле йогынтысында калган шәфигыйләр Коръән һәм Сөннәгә бердәнбер чыганак итеп караганнар, хәдисләрне һәм мәдинәлеләрнең иҗмагын беренче дип искәрмәсез кабул иткәннәр, кыяс киң кулланылган, истихсан кире кагылган, ләкин истислах (ирекле фикер йөртү нигезендә дә, гореф-гадәтләр нигезендә дә) нык үзләштерелгән. Хәнбәлиләр барлык тәфсирләрне кире какканнар, Сөннәнең әһәмияте Коръән дәрәҗәсенә күтәрелгән; дини тәгълиматларны акылга нигезләп шәрехләүгә юл куелмаган; иҗмагъ Мөхәммәд пәйгамбәр сәхәбәләренең беренче буыны тарафыннан чикләнә. Хәнбәлиләр, акылга нигезләнгән фикерне рәсми рәвештә кире каксалар да, охшаш фикергә таянып нәтиҗә ясаганнар. Хәнбәлиләрнең чиктән тыш күрсәтелгән принциплары 18 йөздә, Мөхәммәд ибне Габдел-Ваһһаб (к. *Ваһһабчылык*) тәгълиматларында чагыла.

Мөселманнарның күпчелеге (90%) — сөнниләр, шуларның 30% ка якыны — хәнәфиләр. Хәнәфи мәзһәбе вәкилләренең күпчелеге Әфганстанда, Гайана, Һиндстан, Гыйрак, Пакистан, Сүрия, Төркия, Тринидадта, өлешчә Мисырда, Әзәрбайҗан, Белоруссия, Казакъстан, Россиядә (ш.и. Татарстанда), Урта Азия, Украинада; мәликиләр — Алжирда, Бахрейн, Катар, Кувейт, Мали, Марокко, Нигерия, Судан, Тунис, Чадта, өлешчә югары Мисырда; шәфигыйләр — Мисырда, Иордания, Ливан, Сүрия, Палестинада, өлешчә Көнчыгыш Һиндстанда, Индонезия, Гыйрак, Йәмән, Кения, Малайзия, Пакистан, Россиядә (чеченнәр, ингушлар, аварлар), Танзания, Төркия, Шри-Ланкада; хәнбәлиләр Согуд Гарәбстанында яшиләр.

*Әд.:* Средневековая арабская философия: проблемы и решения. М., 1998; Барковская Ю.В. Мусульманское право и правовая культура. М., 2001; Филипс А-А.Б. Законы жизни мусульман. Эволюция фикха. М., 2002; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991; Мусульманская цивилизация: Энцикл. словарь. М., 2001.

**СӨНЧӘЛӘ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 20 *км* көньяк-көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 519 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710 нан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Вознесенский исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Вознесение чиркәве, земство мәктәбе (1875 тә ачыла), тегермән, ярма яргыч, 2 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1565 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Мукшы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 114 ир-ат; 1859 да — 555, 1897 дә — 885, 1908 дә — 1009, 1920 дә — 1111, 1926 да — 843, 1938 дә — 931, 1949 да — 880, 1958 дә — 718, 1970 тә — 746, 1979 да — 578, 1989 да — 661, 2002 дә — 554 кеше.


**СӨҢГЕ́**, сугыш коралы, озын агач сап башына очлы сөяк, таш яки үткен металлдан ясалган очлык киертелә. Таш гасырдан мәгълүм. Безнең эрага кадәр 7 йөздә Идел-Камада беренче металл очлыклар барлыкка килә.




Бородино хәзинәсе сөңгеләре. Б.э.к. 2 нче меңьеллык уртасы. 1. Алтын бизәкле бронза сөңге; 2. Алтын бизәкле көмеш сөңге.



Бронза гасыр сөңгеләре. Б.э.к. 2 нче меңьеллык уртасы.



Сөңгеләр. 3–7 йөзләр. Идел буе.



Сөңгеләр. 11–13 йөзләр. Идел буе Болгары. ТР Милли музее.



Сөңге. 13–14 йөзләр. Идел буе Болгары.

8–15 йөзләрдә болгарлар дүрткырлы тар, өчкырлы һәм чөй сыман озынча сөңгеләр кулланa. 11–13 йөзләрдә ыргыта торган кыска сөңгеләр, 15–16 йөздә металл сугыш киемен тишәргә сәләтле тар йөзле очлыклы атлы гаскәр сөңгеләре һәм киң йөзле очлыклы ау сөңгесе кулланыла. Еш кына сабына кечкенә сугыш әләмнәре беркетелә. Утлы корал һәм кылычлар барлыкка килгәч, С. киң кулланылыштан төшеп кала.

*Әд.:* Измайлов И.Л. Вооружение и военное дело населения Волжской Булгарии X — начала XIII вв. К.-Магадан, 1997.

*И.Л.Измайлов.*

**СӨРӘ́Н**, татарларның борынгыдан килгән бәйрәм йоласы. Сабан туе алдыннан бер төркем егетләр (5 тән 15 кә кадәр кеше), чәчәкләр һәм тасмалар б-н бизәлгән атларда авыл буйлап йөреп, бәйрәм өчен бүләкләр (чигүле яулыклар һәм сөлгеләр, ирләр күлмәкләре, тукымалар, йомыркалар һ.б.) җыялар (һәр төркем авылның үзенә билгеләнгән өлешендә бүләк җыя). Һәр йорт каршына туктап, кайчак ишегалдына ук кереп, егетләр бүләк алалар һәм аны юкәдән үрелгән кәрзингә, сумкага яисә тубалга сала баралар. С. такмазалар әйтешү, рәхмәт сүзләре, җырлар б-н үрелеп уза. Барлык йортларны да йөреп чыкканнан соң, егетләрнең берсе, бүләкләр тутырылган кәрзинне эләктереп, бөтен көченә авыл кырыена чаптырып китә. Башка чапкыннар аны куып тотарга тиеш булалар; тота алмасалар, бүләкле кәрзин «урлаучы»га була, бу исә бик сирәк күзәтелгән. Җыелган бүләкләр Сабан туен оештыручыларга тапшырыла. 19 йөздә — 20 йөз башында Казан губернасындагы Мамадыш өязенең кайбер авылларында (мәс., Кече Кирмән, Төркәш), бүләкләр җыйганнан соң, егетләр йөгерү, ат чабышы ярышларында көч сынашкан, җиңүчеләргә бүләкләр тапшырылган. Атлы С.нән тыш Лаеш һәм Мамадыш өязләрендә җәяүле С. дә оештырылган. Киенгән-ясанган берничә ир-егет, йорттан йортка йөреп, бүләкләр җыйган, сый-хөрмәт күрсәтүне сораган. С. йоласы татар авылларында хәзерге көнгәчә сакланып калган.

*Әд.:* Уразманова Р.К. Современные обряды татарского народа: Ист.-этногр. исслед. К., 1984; шу л ук. Обряды и праздники татар Поволжья и Урала (годовой цикл XIX — нач. XX вв.): Ист.-этногр. атлас татар. народа. К., 2001; Шарафутдинов Д.Р. Исторические корни и развитие традиционной культуры татарского народа XIX — начала XXI вв. К., 2004.

**СӨРДЕ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 44 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ашыт елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 334 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 2 нче яртысында Печмәнтау (элек Иске Сөрде) авылыннан күченүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Бигашевский Починок, Ясашная Сердобряшка исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, мич чыгару, такта яру, читек тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, җил тегермәне, тимерчелек, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2034,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 150 ир-ат; 1859 да — 673, 1897 дә — 917, 1908 дә — 1174, 1920 дә — 117, 1926 да — 1106, 1938 дә — 843, 1949 да — 586, 1958 дә — 497, 1970 тә — 517, 1979 да — 462, 1989 да — 378, 2002 дә — 347 кеше.

**СӨРЕНЧӘ́К** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 15,5 *км*, бассейнының мәйданы 147,4 *км²*. Елга башы Сарман р-ны Саклаубаш авылыннан 6 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы — Минзәлә р-ны Яңа Мажын авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 67 *м*. Су җыелу мәйданында урман үсемлекләре бөтенләй үсми. С.нең 0,5 тән 8,3 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар, иң зурысы — Шарлык елгасы (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,31 *км/км²*. Туенуы катнаш, яртысыннан артыгы кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 114 *мм*, ташу агымы катламы 61 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,015 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**СӨРКӘЛӘ́Р** (Marmota), тиенсыманнар семьялыгыннан имезүчеләр ыругы. 13 кә якын төре билгеле, Төньяк ярымшарда таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади С. яки байбак (M.bobac) Идел алдында һәм Көнчыгыш Кама аръягында далаланган участокларда яши. Колонияләр хасил итә, аеруча зурлары — *Чыршылы сөркә (байбак) колониясе* (к. «*Дала*»), *Яңа Тинчәле сөркә (байбак) колониясе*, *Үтинкә сөркә (байбак) колониясе*, ш.у. *Чатыр Тау* табигать тыюлыгы составындагы зурая баручы колония.



Гади сөркә.

Гәүдәсенең озынлыгы 62 *см* га, койрыгы 20 *см* га, авырлыгы 10 *кг* га кадәр. Мехы чагыштырмача кыска, тыгыз, йомшак. Кара яки коңгырт чуар комсу-сары төстә, ян-яклары аксыл, корсагы — җирән-сары. Гәүдәсе юан, җыйнаксыз. Аяклары кыска, көчле, тырнаклары казый торган типта. Башы зур, кысылган, муены кыска. Байбаклар ике төрдәге тирән ояларда яшиләр: вакытлыча саклану оялары һәм даими оялар; гаилә б-н (бер оядa 12–15 кә кадәр җанлек) урнашалар. Кышын йокыга талалар. Җенси җитлегү чоры — яшәвенең 3 нче елында. Язын парлашалар, 40–42 көннән 2–8 бала туа. Үләнчел үсемлекләр б-н тукланалар. Халык медицинасында сөркә мае үпкә авыруларын дәвалауда кулланыла. Саны Татарстан терр-ясендә арту сәбәпле, гади С. ТРның Кызыл китабыннан чыгарылган (2006).

**СӨТ ҺӘМ СЫР-МАЙ ҖИТЕШТЕРҮ́ СӘНӘГАТЕ́**, җиңел сәнәгатьнең төрле сөт продуктлары — аертылмаган сөт продукциясе, май, сөт консервлары, коры сөт, сыр, брынза, туңдырма, казеин һ.б.ны җитештерүче пр-тиеләрне берләштергән тармагы. ТРда 50 пр-тие: сөт комб-тлары һәм з-длары, сөт-сыр з-длары һәм цехлары; транспорт, сәүдә оешмалары һ.б. бар. Иң эре җитештерүчеләр: «Просто молоко» ҖЧҖ идарәче компаниясе (аның составына Аксубай май з-ды, Бөгелмә, Казан, Чаллы, Түбән Кама сөт комб-тлары, Мамадыш сыр-май комб-ты, Мөслим һәм Яңа Чишмә коры сөт з-длары керә), «*Алексеев сөт-консерв комбинаты*» ҖЧҖ, «Эдельвейс-М» сөт продуктлары комбинаты» АҖ, «Эдельвейс-М» ҖЧҖ (Казан), «Эдельвейс-Кукмара» ҖЧҖ, «Яшел Үзән сөт комбинаты», «Челны-холод» (Чаллы ш.), «Алабуга сөте», «Чистай сөт комбинаты», «ТОРОС-МОЛОКО» (Лениногорск ш.) АҖ һ.б. эшли. Тәүлеккә 50–100 *т* сөт эшкәртүче пр-тиеләр өстенлек итә, эрерәк пр-тиеләр тәүлеккә 500, 700, 1000 *т* сөт эшкәртә.

Казан губернасында беренче сөт эшкәртүче пр-тиеләр 19 йөз ахырында барлыкка килә (1884 елда алпавыт Н.П.Бельковичның Лаеш өязе Надеждинский авылындагы утарында сыр кайнату оештырыла). Соңрак кечерәк күләмнәрдә май һәм сыр җитештерү кайбер алпавыт хуҗалыкларында һәм Казан губерна земствосының 2 нче а.х. фермасында җайга салына. 1893 тә Казан икътисадчылар җәмгыяте уздырган а.х. продуктлары күргәзмәсендә атланмай, Париж, Голштиния майлары, Бакштейн сыры күрсәтелә. 20 йөз башында май җитештерү үсеш ала. 1910 да Чистай өязенең Мамык авылында 1 нче май эшләү, сыр кайнату һәм терлекчелек мәктәбе ачыла; Зөя, Казан, Лаеш, Спас, Тәтеш, Чистай өязләрендә һәм Малмыж шәһәрендә махсус май җитештерү осталары әзерләү курслары оештырыла. 1911 дә губерна терр-ясендә 38 май эшләү пр-тиесе, ш.и. 2 кечерәк май з-ды (Спас өязенең Пичкас авылында һәм Зөя шәһәрендә) була, алар атланмай һәм эретелгән май, каймак чыгаралар. 1913 тә 50 май эшләү пр-тиесе исәпләнә, май җитештерү елга 40 *т* тәшкил итә. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, күп кенә май эшләү пр-тиеләре ябыла, Гражданнар сугышы елларында калган пр-тиеләр дә продукция чыгаруны туктата.

1920 еллар ахырында сөт җыю һәм эшкәртү, май, сыр җитештерү, аларны сату эшчән-

леге яңара. 1927 дә халыктан сөт кабул итү һәм эшкәртү буенча 26 кооператив пункт оештырыла. 1928 дә аларның саны 51 гә җитә (38 артель һәм 13 а.х. кредит ширкәте), ш.и. 39 май эшләү, 6 сыр кайнату, 3 сөт җитештерү, 3 сепаратор пр-тиесе була. Сөт (14,3 мең *т*) 388 авылдан җыела. 1930 да ТАССРда 160 зур булмаган сөт эшкәртү пр-тиесе (104 — май, 31 — сыр, 25 сөт з-ды) эшли, алар «Татарстан май җитештерү берлеге» («Татмаслосоюз», 111 пр-тие), «Татарстан кулланучылар берлеге» («Татпотребсоюз», 10 пр-тие), район кооперация берлекләренең (39) яраклаштырылган биналарында урнаша. Заводларның күпчелеге Чаллы (20), Минзәлә (16) һәм Спас (12) р-ннарына туры килә. Тармакта сөт эшкәртү кустарь ысуллар б-н башкарыла. Заводлар һәм сепаратор пунктларының җиһазлары су җылытулы тартмалардан, сәгатькә 300 *л* чамасы җитештерүле төрле маркалы кул сепараторларыннан, сыр, эремчек һәм казеин эшләү өчен 500–700 *л* сыйдырышлы агач чаннардан, 60–100 *л* лы гөбеләрдән, май эшкәрткечтән һ.б. вак инвентарьдан гыйбарәт була. Җитештерелгән продукция базларда саклана. Кабул итү пунктларына сөт атлар һәм үгезләр җигелгән олауларда китерелә. 1932 дә барлык заводлар һәм районара май базалары (әзерләү пунктлары) яңа оештырылган Татарстан «Союзмаслопром» өлкә бүлекчәсе (1934 тә «Татмаслопром» тресты итеп үзгәртелә, 1959 га кадәр эшли) составына кертеләләр. 142 пр-тиенең 113 ен май, 29 ын май-сыр з-длары тәшкил итә, аларга чимал 127 сепаратор һәм 1820 май җыю бүлекчәләреннән җибәрелә. 1933 тә җитештерелгән продукция (*т*): май — 1393, майлы каты сырлар — 148, майсызландырылган эремчек — 1736, казеин — 5.

1930 елларда дәүләт сөт һәм май з-длары төзелә. Казанда Үзәк сөт з-ды (1932), Урманай май-казеин з-ды (Азнакай р-ны), Алексеев коры сөт з-ды (икесе дә 1935 тә), Әлмәт р-нының Әлмәт, Әгерҗе р-нының Тирсә авылларындагы май з-длары, Шәйморза р-нының Борындык авылындагы май-сыр з-ды (барысы да 1938 дә) сафка баса.

1936 да Алексеев, Биләр, Лаеш, Спас һәм Чистай р-ннарындагы май з-длары Алексеев коры сөт з-ды карамагына тапшырыла. Коры сөт җитештерү 80 *т* тәшкил итә. 1940 та респ-када 132 сөт эшкәртү з-ды («Татмаслопром» трестында — 90, Казан «Росглавмолоко» шәһәр сөт з-дында — 26, Алексеев коры сөт з-дында — 16), ш.и. 1 коры сөт, 1 шәһәр сөт, 71 май, 19 май-сыр, 40 башлангыч сөт з-длары була. Бөек Ватан сугышы елларында тармак пр-тиеләре фронт, хәрби з-длар, госпитальләр һәм балалар учреждениеләре ихтыяҗларына эшли. 1941–49 да, Казан шәһәр сөт з-дыннан һәм Алексеев коры сөт з-дыннан кала, барлык заводларда да эш кул көче б-н башкарыла, аларда сөт һәм сөт өсте су җылытулы тартмаларда эшкәртелә.

1950–60 елларда тәүлеккә 100 *т* сөт эшкәртүгә сәләтле Казан сөт з-ды (хәзер «*Казан сөт комбинаты*» АҖ), һәрберсе елга 2000 *т* сөт эшкәртү куәтенә ия Бөгелмә, Алабуга, Иштирәк, Нурлат-Октябрь май з-длары, һәрберсе тәүлеккә 10 *т* сөт эшкәртерлек Балтач, Буа, Кормаш, Теләнче Тамак май з-длары, Аксу, Мөчәли — сыр, Зеленково, Питрәч, Чирково сөт з-длары файдалануга тапшырыла. Минзәлә һәм Чирмешән — сыр, Чистай сөт з-дларында реконструкция уздырыла. Яңа төзелгән һәм реконструкцияләнгән пр-тиеләр электр энергиясе б-н тәэмин ителә, пар казаннары, кайберләре суыткыч-компрессор җайланмалары б-н җиһазландырыла. Аерым заводларда һәм сепаратор пунктларында сепараторларны, май язгычларны моторлаштыру, цехлар эчендә чимал һәм ярымфабрикатларны күчерү өчен насослар кую, өзлексез линияләр, тутыру-ябу автоматлары, механик болгаткычлы сыр ванналары, эретелгән сырлар эшләү өчен автомат җиһазлар куллануга кертү юлы б-н күп хезмәт таләп ителә торган процесслар өлешчә механикалаштырыла. 1963 кә 38 май заводында май җитештерү өчен өзлексез эшләүче линияләр урнаштырыла; пр-тиеләрнең 30% ы пар б-н механикалаштырыла. 1959–60 та 111 завод һәм 65 сепаратор бүлекчәсе эреләтелә, 10 сөт һәм май-сөт комб-тына берләштерелә. Җитештерелгән продукция ассортименты 20 исемдә була. 1960 елларда барлык заводлар һәм сепаратор пунктлары пар б-н механикалаштырыла, технол. җиһазларны яңарту дәвам итә. 1970 кә, 1960 ел б-н чагыштырганда, продукция җитештерү 2 тапкырдан күбрәккә арта (к. табл.).

1940–2013 тә Татарстан сөт һәм сыр-май җитештерү сәнәгате продукциясенең төп төрләрен эшләп чыгару, мең *т*

| Еллар | Сөткә күчереп исәпләгәндә аертылмаган сөт продукциясе | Майлы сырлар[1] | Май[2] | Туңдырма[3] |
|---|---|---|---|---|
| 1940 | 6,1 | 0,4 | 2,5 | ... |
| 1950 | 11,1 | 0,5 | 3,8 | ... |
| 1960 | 105,3 | 2,3 | 11,1 | ... |
| 1970 | 245,6 | 5,2 | 15,7 | ... |
| 1980 | 333,0 | 7,2 | 20,4 | ... |
| 1990 | 479,4 | 10,3 | 30,8 | 11,5 |
| 1995 | 204,4 | 6,9 | 28,9 | 9,6 |
| 2005 | 185,2 | 33,3 | 20,4 | 13,4 |
| 2006 | 221,8 | 39,5 | 22,0 | 9,6 |
| 2013 | 359,7 | 15,7 | 12,9 | 16,3 |

1) 2009 дан сырлар һәм сыр продуктлары.
2) 2009 дан атланмай һәм май пасталары.
3) 2009 дан туңдырма һәм туңдырылган десерт ризыклар.

1970 елларда яңа пр-тиеләр — Түбән Кама (тәүлеккә сөт эшкәртү куәте — 50 *т*), Бөгелмә, Саба (25 әр *т*; барысы да 1972 дә), Чаллы (150 *т*, 1973) сөт з-длары, ш.у. Актаныш р-нының «Чишмә» к-зында, Әлмәт р-нының «Нефтяник» с-зында һәм Казан ат з-дында (Питрәч р-нының Званка авылында) кымыз эшләү цехлары файдалануга тапшырыла. 1970 еллар уртасына еллык җитештерү (мең *т*): май — 20, майлы сырлар — 5. Тармак пр-тиеләре төрле исемдәге һәм майлылыктагы (30–60%) табигый голланд, пошехон, Кострома, эстон, Россия, сулугуни, чәй сырлары, майсызландырылган, колбаса рәвешендәге һәм эретелгән сырлар җитештерүне үзләштерәләр. 1973 тә каплы продукция чыгару (гомуми күләмнән % ларда): сөт — 29,6, каймак — 27, майлы эремчек — 40 (1965 тә бу күрсәткечләр тиңдәшле рәвештә 16,4; 7,3 һәм 9,2% тан артмый). 1970–80 елларда пр-тиеләрдә ачы сөт продуктлары — резервуар ысулы, эремчекне аерым алым б-н җитештерү, оеткыларны стерильләштерелгән сөттән әзерләү, майсызландырылган сөт продукциясе эшләү, пахта һәм сыворотка куллану гамәлгә кертелә. Ассортимент 70 исемгә кадәр үсә (1975). Сөтне дәүләтнең сатып алу һәм эшкәртү күләме 648,3 мең *т* дан (1970) 1214,5 *т* га кадәр (1989) арта.

Сөт җитештерү сәнәгате пр-тиеләре 1960–65 тә — Татарстан ХХСның Ит-сөт җитештерү идарәсе, 1965–71 дә — Татарстан сөт әзерләүләр һәм сөт җитештерү сәнәгате респ-ка идарәсе, 1972–90 да — Татарстан сөт җитештерү сәнәгате респ-ка берләшмәсе, 1990–94 тә ТР Аграр сәнәгате «Татарстан сөт-аграр сәнәгате» («Татмолагропром») ҖБ карамагында була. Икътисади реформалар башлангач, тармак пр-тиеләре дәүләт карамагыннан хосусый милеккә күчәләр, акц. җәмгыятьләренә әвереләләр. 1994 тә «Татарстан сөте» холдинг компаниясе» АҖ (2006 да «ВАМИН-Татарстан» АҖ итеп үзгәртелә), 1995 тә «Эдельвейс-М» ҖЧҖ оештырыла. 2006–12 дә ТРда «ВАМИН-Татарстан» АҖ эшли. 2013 тән ҖЧҖ «Просто молоко» ИК эшли башлый. «Просто молоко» АҖ идарәче компаниясе тулы җитештерү циклы үзенең агрофирмалары, сөт з-длары булган ТРда бердәнбер иң эре сөт эшкәртүче а.х. пр-тиесе. Аның бүгенге көндә 3 сөт з-ды, 6 сөт комб-ты, 15 агрофирмасы, 1 элеваторы, 4 икмәк кабул итү пр-тиесе, 1 катнаш азык з-ды бар. «Просто молоко» елга 160 мең *т* аертылмаган сөт продукциясе, 8 мең *т* ак май, 8 мең *т* сыр һәм сыр эшләнмәләре җитештерә. «Просто молоко» АҖ идарәче компаниясенә товар әйләнешенең 40% ы, «Эдельвейс-М» ҖЧҖнә 33% ы туры килә (2014). Продукция сату базарына ия булу өчен барган көндәшлек тармакның алга таба үсешенә этәргеч бирә. Эшкәртү өчен чимал башлыча ТР сөт җитештерүчеләреннән, өлешчә читтәш төбәкләрдән китерелә.

С.һ.с.-м.җ.с. 200 гә якын төрдә продукция, ш.и. 100 дән артык исемдә аертылмаган сөт продуктлары чыгара. 1990–2005 тә сөт продукциясенең 100 гә якын яңа төрен җитештерү үзләштерелә. Алар арасында — каты сырлар (20 төр), төрле йогуртлар, бифидобактерияләр б-н баетылган «Бифидок» кефиры, ряженка, «Бифидум» һәм «Бифилайф» дәвалау ачы сөт продуктлары, диетик һәм майлы эремчек, фторланган һәм йодланган сөт, сөзмә, корт, төрле эчемлекләр, туңдырмалар һ.б.

Тармакта җитештерелүче продукциянең 25 төре (шулар арасында шоколад йөгертелгән эремчек батончыклары, «Голландский», «Гауда» сырлары, катык, каймак, «Пошехонский», «Костромской» сырлары һ.б.) «Россиянең иң яхшы 100 товары» исәбенә кертелә, Бөтенроссия «Алтын көз» агросәнәгать күргәзмәсе (Мәскәү), Бөтенроссия сырлар сыйфаты конкурс-смотры (Крас-

нодар, Барнаул шәһәрләре), Халыкара «Продэкспо» ярминкәсе (2003, 2004, 2005, 2006, 2014, 2015) медальләре һәм дипломнары б-н бүләкләнә. «Просто молоко» АҖ идарәче компаниясе 2015 тә Берлинда узган «Зелёная неделя» күргәзмә-ярминкәсендә 3 алтын медальгә лаек була. Продукция (25% чамасы) РФнең 5 тән артык төбәгенә (Мәскәү, С.-Петербург, Самара, Уфа, Ижевск, Пермь) җибәрелә.

Тармак пр-тиеләре өчен инженер-техник белгечләрне — Казан технол. ун-ты, Казан механика-технол. техникумы һ.б. уку йортлары, эшче кадрларны 49 нчы һөнәр уч-щесе (Казан) әзерли.

*Әд.:* Донбулатов М.Ш., Закиров Т.З. Молочная промышленность Татарии. К., 1974; ОАО «Казанский молочный комбинат»: От прошлого — в будущее. К., 2002; Ксенофонтов Е.А. ОАО «Чистопольский молочный комбинат» // Молочная пром-сть. 2004. № 6.

*К.Ф.Фәсхетдинов, М.Ж.Гаитов.*

**СӨТЛЕ́ САБА́К**, к. *Агулы билчән.*

**СӨТЛЕГӘ́Н** (Euphorbia), сөтлегәнчәләр семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләннәр һәм куаклар ыругы. 2 меңгә якын төре билгеле, бөтен Җир шарында, күбесенчә тропик һәм субтропикларда таралган. ТР терр-ясендә 11 төре: Саз С.е (E. palustris), чуклы С. (E. semivillosa), чыбыксыман С. (E. virgata) барлык районнарда очрый; күгелҗем С. (E. caesia), очлы С. (E. esula), рус С.е (E. rossica) һ.б. — сирәк төрләр. Кырларда, юл буйларында, куаклар арасында, җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчаларында үсә. 2 *м* га кадәр биеклектәге бер- яки күпьеллык үләнчел үсемлек. Яфраклары чиратлашкан, озынча формада. Чәчәкләре күрексез, саргылт-яшел төстә, бер җенесле, вак, бер ана һәм 10–12 ата чәчәкләрдән торучы чатыр чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — өч оялы тартмачык. Май–августта чәчәк ата. Җимешләре июньнең 2 нче яртысы – августта өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл (тамыр үрентеләре) б-н үрчи. Үсемлекнең барлык өлеше дә сөтчел сыекчалы, ул тирегә эләккән очракта, озак төзәлүче пешү, ялкынсыну җәрәхәтләре китереп чыгара. Үсемлектә сумала, сапонин, флавоноид, кумарин бар. Халык медицинасында С. ревматизм, подагра һәм эч йомшарту чарасы буларак, сөялләрне бетерү өчен, гөмбә авырулары (аяк өчен ванналар) вакытында кулланыла. Чыбыксыман С., очлы С., көнбагар С. (E. helioscopia) һ.б. — чүп үләннәр. Гмелин С.е (E. gmelinii) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**СӨЯКӘ́Й** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 34 *км* көнчыгыштарак, Калмыя елгасы буенда. 2010 елда 130 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1795 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Суякеева, Сююкеева исемнәре б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы асабалар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, мәчет, мәктәп, су тегермәне эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1467,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әмәкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1816 да — 55 ир-ат; 1859 да — 182, 1870 тә — 224, 1913 тә — 645, 1920 дә — 558, 1926 да — 405, 1938 дә — 435, 1949 да — 368, 1958 дә — 338, 1970 тә — 348, 1979 да — 262, 1989 да — 177, 2002 дә — 144 кеше.

**СӨЯКЧӘННӘ́Р** (Lithobiomorpha), иренаяклы күбаяклылар отряды. Якынча 800 төре билгеле. Татарстан урманнарында 8 төре очрый. Гади С. (Lithobius forficatus) киң таралган. С. — җир өсте буынтыгаяклылары. Гәүдәсе 3–50 *мм* озынлыкта. Баш һәм 19 сегменттан (зур сегментлар кечкенәләре б-н чиратлашa) торучы гәүдә (күкрәк) өлешләренә бүленгән, аларның һәрберсендә парлы аяклар урнашкан. С. урман түшәлмәсендә, черек агачта, ташлар астында, болын һәм дала үләнчел үсемлекләре калдыкларында яшиләр; яшерен яшәү рәвеше алып баралар. Дым яратучаннар һәм бик хәрәкәтчәннәр. Еркычлар, вак умырткасызлар (нигездә, бөҗәкләр) б-н туеналар. Еш кына күкәйләрен җир кузыга салалар.

**СӨЯ́Л ҮЛӘНЕ́** (Lapsana), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 10 га якын төре билгеле. ТР терр-ясендә бер төре — гади С.ү. (L. communis) бар. Сирәкләнгән урманнарда, урман, юл буйларында, чәчүлекләрдә чүп үлән буларак үсә. 20–100 *см* биеклектәге берьеллык үсемлек, тармаклы туры сабаклы. Өске яфраклары бөтен, аскылары каурыйсыман-теленмә. Чәчәкләре аксыл-сары, себеркәч — калкан чәчәк төркеменә җыйналган күп санлы вак кәрзиннәрдә. Җимеше — орлыкча. Июнь–июльдә чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Үсемлектә каротин, аскорбин к-тасы бар. Тамыры һәм үләне төнәтмәсе буылуга (спазмага), ялкынсынуга каршы, бөрештергеч чарага ия. Халык медицинасында үлән суы һәм төнәтмәсе тире авырулары вакытында кулланыла.

**«СПАРТА́К»**, Казандагы аяк киемнәре пр-тиесе. 1916 елда сәнәгатьчеләр В.Г.Шабанов, Н.М.Зобнин һәм С.В.Жулин тарафыннан, пайлар берләштереп, «Поляр» ф-касы буларак нигезләнә. 1920 дә национализацияләнә. 1922 дән Казан «С.» күн аяк киемнәре комб-ты, 1963 тән Татарстан аяк киемнәре җитештерү берләшмәсе, 1989 дан Татарстан сәнәгать-сәүдә аяк киемнәре берләшмәсе (1991 дән арендада), 1994 тән «С.» аяк киемнәре берләшмәсе» АҖ, 1996 дан «С.» аяк киемнәре АҖ, 2002 дән «С.» АҖ, 2003 тән «С.» аяк киемнәре фабрикасы» АҖ. Башта Швеция «Атлас һәм Поляр» электр двигателе һәм аяк киемнәренең өске өлешен тегә торган Америка машиналары б-н җиһазландырылган (башка операцияләр кулдан башкарылган) фабрикада 2 төр продукция — солдат итекләре һәм ботинкалар (1916 да — 180 мең пар, эшләүчеләр саны — 300 кеше; 1919 да — 405 мең пар, 980 кеше) чыгарыла. Чимал фабрика янәшәсендәге күн з-дыннан алына. Гражданнар сугышы тәмамланганнан соң, продукция җитештерү 5 тапкыр кими; 1925 тә җиһазлар торгызыла, яңа техника килә башлый. 1929–33 тә яңа аяк киемнәре тегү техникасы һәм киптерү камерасы куллanылышка кертелү, җитештерү мәйданнары зурайтылу нәтиҗәсендә комб-тта хезмәт җитештерүчәнлеге 60% ка, эшләүчеләр саны 2,8 мең кешегә кадәр, 1929–39 да продукция күләме 560 меңнән 1,7 млн. парга кадәр арта. Бөек Ватан сугышы чорында комб-т эвакуацияләнгән «Труд» (Гомель ш.) һәм «Скороход» (Ленинград) аяк киемнәре ф-каларының җиһазларын һәм эшчеләрен кабул итә. «С.»та илдә беренче тапкыр сәнәгый, нигездә, мех унталар җитештерү җайга салына, Ленинград ф-касы тәҗрибәсенә нигезләнеп, аяк киемнәрен кайнар вулканлаштыру алымы б-н тегү үзләштерелә, ябыштырыла торган аяк киемнәре өчен пресслар, рант тегү машиналары урнаштырыла, өзлексез эшләү оештырыла, бу, 1942 дән башлап, ел саен фронтка



«Спартак» аяк киеме фабрикасы АҖ. Әзер продукция цехы.

1 млн.нан артык пар армия итекләре җибәрү мөмкинлеге бирә. Сугыштан соңгы елларда хатын-кызларның — модельле, ирләр, балалар өчен, өйдә кия торган һ.б. төрле аяк киемнәре тегү цехлары ачыла. Алга таба, бер үк вакытта корпусларны реконструкцияләү б-н бергә, технол. процессның барлык стадияләрен комплекслы механикалаштыру һәм конвейерлаштыру җәелдерелә, ясалма һәм синтетик материаллар киң кулланыла башлый. 1960 елларда пр-тие составына Казанда урнашкан балалар аяк киемнәре ф-касы, Казан, Яшел Үзән һәм Чистай аяк киемнәре ф-калары керә; цехларны кушу һәм үзгәртеп корулар гамәлгә ашырыла. 1960 еллар ахыры — 1970 еллар башында Мамадыш, Йошкар-Ола шәһәрләрендә, Актаныш р-нының Актаныш, Балык Бистәсе р-нының Котлы Бөкәш, Саба р-нының Олыяз авылларында һ.б. җирләрдә производстволар, 1980 елларда Казан, Түбән Кама, Әлмәт, Зәй, Чистай, Йошкар-Олада фирма кибетләре ачыла. 1990 га «С.» составына 25 комплекслы-механикалаштырылган цех керә (эшләүчеләр са-

ны 6 мең кешегә якынлаша); 5 мең берәмлек алдынгы технол. җиһаз (аларның 45% тан артыгы югары җитештерүчәнлек күрсәткечләренә ия була), аяк киемнәренең аскы өлеше детальләрен эшкәртү һәм аяк киемнәрен җыю буенча 7 ярымавтомат линия, 4 *км* озынлыктагы конвейер линияләре файдаланыла. 1990 еллар башында 100 дән артык операцияне үз эченә алган технол. процессның механикалаштырылу дәрәҗәсе 67% ка җитә. 1955–90 да аяк киемнәре ассортименты 66 дан 250 модельгә кадәр, продукция (электкечә үк аның төп өлешен армия өчен аяк киемнәре тәшкил итә) эшләп чыгару күләме елга 5 млн.нан (1958) 10 млн. парга кадәр арта. 1990 еллардагы икътисади кыенлыклар җитештерүнең кискен кимүенә (1998 дә 184,3 мең парга кадәр) һәм филиалларның ябылуына китерә. 1999 да «Татфондбанк» һәм «ТатИнК» инвестиция компаниясе катнашында җитештерү үзгәртеп корыла, аяк киемнәрен автоматлаштырылган проектлау җиһазлары сатып алына, продукция ассортименты шактый киңәйтелә.

2014 кә «С.»ның төп (өлгеләү-кисү, аяк киемнәренең өске өлеше эшләнмәләрен җыю, әзер продукция тегү) һәм ярдәмче цехларында һ.б. бүлекләрендә 650 дән артык кеше эшли. Продукция Россия климаты шартларына яраклаштырылган ирләр, хатын-кызлар һәм балалар аяк киемнәренең киң ассортиментыннан гыйбарәт. «С.» продукциясе «С.», «Bonton» һәм «Poliar» сәүдә маркалары б-н чыгарыла. Яңа коллекцияләр даими маркетинг тикшеренүләре нигезендә булдырыла. «С.» Россиянең 10 иң эре аяк киемнәре җитештерүчеләре исәбенә керә. Еллык җитештерү күләмнәре: 2002 дә — 695,4 мең пар, 2005 тә — 524,5 мең пар, 2013 тә — 290 мең пар. Продукция 80 нән артык кибетне (Татарстан, Башкортстан, Чуаш, Удмурт, Мордва, Мари Респ-каларының һәм Түбән Новгород өлкәсенең 20 дән артык шәһәрендә) эченә алган үз сәүдә челтәре, ш.у. күптармаклы дистрибьюторлар челтәре аша сатыла, БДБ илләренә чыгарыла. Җитештерү өчен материал Мәскәү, С.-Петербург, Ярославль, Киров, Ростов-Дон һ.б. шәһәрләрнең 20 пр-тиесеннән китерелә.

Бөек Ватан сугышы елларында «С.» коллективына берничә тапкыр СССР Дәүләт Оборона Ком-тының күчмә Кызыл байрагы бирелә, 1945 тә ул мәңгелек саклауга тапшырыла. Пр-тие бүләкләре арасында — СССР һәм РСФСР Җиңел сәнәгать халык комис-тлары һәм министрлыклары, ВЦСПС, КПСС һәм ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тлары, профсоюзларның өлкә советы, ТАССР МС һәм ЮС Президиумы байраклары һәм дипломнары. «С.» аяк киемнәре үрнәкләренә күп тапкырлар «Россиянең иң яхшы 100 товары» билгесе бирелә. Күп кенә эшчеләре дәүләт бүләкләренә лаек була: 1 кешегә — Соц. Хезмәт Герое, 7 кешегә РСФСР, ТАССРның атказ. җиңел сәнәгать хезмәткәре исемнәре бирелә; 9 кеше — Ленин ордены, 3 кеше — Октябрь Революциясе, 21 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 3 кеше — Халыклар дуслыгы, 51 кеше — «Почёт билгесе», 2 кеше — 2 нче дәрәҗә Хезмәт Даны, 37 кеше — 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны орденнары, 500 гә якын кеше медальләр б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре арасында — Н.М.Зобнин (1916–18), Гардеев (1930 еллар), П.А.Ситников (1941–42), Д.И.Яковлев (1943), Н.С.Сметанин (1943–46), М.А.Карнаухов (1946–59), М.М.*Аблаев* (1959–80), Г.Х.*Кыямов* (1980–96), Ф.Р.Әхмәтҗанов (1996–99), Р.З.Гарипов (2003–13), И.И.Зарипов (2013 тән).

*Әд.:* Очерки истории Татарского обувного объединения «Спартак». К., 1966.

**«СПАРТА́К-ТАТАРСТА́Н»**, физкультура-спорт җәмгыяте. 1937 елда «Спартак» ирекле спорт җәмгыятенең Татарстан респ-ка советы, 1999 дан хәзерге исемдәге мөстәкыйль оешма (җитәкчесе — Г.А.Джапаридзе). «Спартак» ирекле спорт җәмгыятенең Татарстан советы җиңел һәм азык-төлек җитештерү сәнәгате, сәүдә, сәнәгать кооперациясе, мәдәният, мәгариф һәм сәламәтлек саклау, коммуналь хуҗалык, элемтә, автотранспорт, гражданнар авиациясе учреждениеләре эшчеләре һәм хезмәткәрләренең, һөнәри оешмалар укучыларының 384 физик культура коллективын берләштерә. Аларда ишү (академик, байдаркада һәм каноэда), чаңгы һәм велосипед спорты, җиңел атлетика, акробатика, баскетбол, көрәш (грек-рим, ирекле), чаңгыда трамплиннан сикерү, чаңгыда ике төр ярыш, шахмат, чирәмдә хоккей, өстәл теннисы үсеш ала. СССРның 3 халыкара класслы спорт остасы, 150 спорт остасы әзерләнә. Иң яхшы тренерлар һәм спортчылар: Ю.А.Бабушкин, О.Б.*Вощакина*, М.М.Гаврилова, В.Т.Глухих, В.А.Гоголин, В.М.Колесов, С.И.Кунышина, И.М.*Мөхәрләмов*, Р.Г.*Нәҗметдинов*, А.И.Панкова, М.М.Унгвицкий, М.Х.Фәйзрахманов, Ә.Ш.*Шәйхетдинов*, Т.С.Спиридонова (1947–51), А.Г.Батыршин (1951–53), Р.К.Бажина-Шәрәфиева (1970–71), В.А.Смолин (1971–77), Ф.Г.Гыйльметдинов (1977–87).

1999 дан «С.-Т.» транспорт һәм юл хуҗалыгы, сәламәтлек саклау, элемтә, төзелеш, архит-ра һәм торак-коммуналь хуҗалык, сәүдә һәм тышкы икътисади хезмәттәшлек министрлыклары каршындагы, ш.у. респ-ка профсоюзлары каршындагы машина төзелеше тармагын, дәүләт учреждениеләрен, җәмәгать хезмәт күрсәтү учреждениеләрен, «Татэнерго», «Татнефть», оборона, авиация һәм химия сәнәгате физик культура коллективларын һәм иҗтимагый советларны берләштерә. 2014 нең башында җәмгыять ТРның төрле милек формалары пр-тиеләре һәм оешмаларының 1300 физик культура һәм спорт коллективын үз эченә ала, аларда 200 меңнән артык кеше шөгыльләнә. ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы, ТР профсоюзлар федерациясе һәм тармак профсоюзлары ярдәме б-н «С.-Т.» ел саен массакүләм физкультура-спорт чаралары уздыра, аларда 200 дән артык физкультура коллективларыннан 7 мең кеше шөгыльләнә. Пр-тиеләрнең иң яхшы коллективлары — «Метроэлектротранс», «Түбәнкаманефтехим», «Татнефть», «Татэлектромонтаж», Әлмәт насослар заводы, «Казанькомпрессормаш», «Таттелеком», «Бөгелмә авиапредприятиесе», Казан вертолёт з-ды, ТРның радио- һәм телетапшыру үзәкләре. ТР җыелма командасы Россия сәнәгать тармаклары физик культура һәм спорт клубларының 6 нчы фестивалендә «Уңышлы дебют өчен» кубогы б-н бүләкләнә (Чабаксар, 2008), 22 нче Бөтенроссия мәдәни-спорт фестивале ярышларында (гомумкоманда зачётында) җиңүче (Мәскәү, 2014).

**СПАС**, Болгар шәһәренең 1926 елга кадәрге атамасы.

**СПАС** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 19 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Дим елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 598 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 57%, татарлар — 35%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1743 тә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рычково (авылның беренче хуҗасы — П.И.*Рычков* исеме б-н бәйле) буларак та билгеле. Халкы башта алпавыт крәстияннәре катлавына керә, 19 йөз башында — ирекле игенчеләр, 1848 дә дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлек асрау, тәгәрмәч, чүлмәк ясау, йон-тукыма ману б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Вознесение чиркәве (1765 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе, су тегермәне, земство станциясе эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2551 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Спас волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 296, 1889 да — 187, 1897 дә — 530, 1910 да — 630, 1920 дә — 970, 1926 да — 648, 1938 дә — 1320, 1949 да — 934, 1958 дә — 1070, 1970 тә — 767, 1979 да — 549, 1989 да — 311, 2002 дә — 237 кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**«СПАС»**, комплекслы табигать тыюлыгы. Спас р-ны терр-ясендә урнашкан. Яр буе утрауларын (64 утрау) һәм Куйбышев сусаклагычының сай сулыкларын били. 2001 елда билгеләнә. Мәйданы 17979 *га*. Сусаклагычта кәсәбәчелек балык төрләренең (чөгә, чуртан, сазан, корбан балык, густера, опты, җәен, сыла, бёрш) иң зур уылдык чәчү мәйданнары урнашкан; Иделдә кырпының иң соңгы яшәү урыннарыннан берсе. Спас архипелагы Рос-



«Спас» табигать тыюлыгы.

сиянең төп орнитология терр-яләре (КОТР) һәм халыкара әһәмияткә ия булган аеруча кыйммәтле су-сазлык җирләренең перспектива исемлекләренә кертелә. Елга каракошының иң зур резерватларыннан (9 парга кадәр оялый) берсе, сапсанның ау урыны. Ысылдавык аккошның респ-када иң зур төркеме (12 пар) тыюлык терр-ясендә яши, бирегә зур ак челән, алсу фламинго, көдрәч пеликан очып керә. Биредә беренче тапкыр 1924 тә Спас шәһәреннән 3–4 *км* төньяктарак зоолог И.С.Башкиров тарафыннан табылган дала кара еланының ТРда бердәнбер һәм ареалда иң төньяк популяциясе (1991 дән — 50 *га* мәйданы булган табигать истәлеге) яши. Тыюлык флорасы көпшәле үсемлекләрнең 448 төреннән тора. Амфибияләрнең — 7, рептилияләрнең — 5, оя коручы кошларның — 114, имезүчеләрнең 39 төре билгеләнгән. Сирәк һәм югала баручы төрләр: үсемлекләр — Себер сусыны, дарулы бизгәк үләне, рус кырыкбуыны, киң яфраклы йод үләне, кырпулы лалә, ап-ак лилия, йөзгәләк сальвиния; хайваннар — бакыр кәлтә, зур күлбога, болын карчыгасы, бытбылдык, кызылаяк шөлди, карабаш шаркылдык, нәни акчарлак, кече крачка, сазлык ябалагы, гади яр чыпчыгы, сары корташар, соры карабай, яр песнәге, ас.

*В.И.Гаранин, Ю.И.Павлов.*

**СПАС КАНТОНЫ́**, 1920–30 елларда ТАССРдагы адм.-терр. бүленеш берәмлеге. Үзәге — Спас шәһәре (Татар Спасы ш.). Спас өязе волостьлары җирлегендә барлыкка килә. Мәйданы — 4830 *км*². Халкы 138581 мең кеше, ш.и. руслар — 81118, татарлар — 42034, чуашлар — 11278, мордвалар — 3920 (1926). Шәһәр халкы саны — 6039, авыл халкы — 132542 кеше. 1 *км² га* халык тыгызлыгы — 28,7, авылда — 27,4 кеше. 282 авыл торак пункты. 143 мәктәп (1927). 8 волость: Әлки, Базарлы Матак, Кузнечиха, Левашёво, Спас, Тигәнәле, Өчкүл, Юхмачы волостьлары. Металл эшкәртү һәм азык-төлек сәнәгате пр-тиеләре. Кантонның кустарь-һөнәрчелек җитештерүенә 2 меңнән артык кеше җәлеп ителә (1926). 1925 кә С.к.нда 29533 крәстиян хуҗалыгы, 46 а.х. кооперативлары исәпләнә; сөрелгән җир мәйданы 239366 дис.: арыш — 56425, тары — 17791, солы — 15274, карабодай — 6769, бодай — 6082, борчак — 5557, борай — 2284, ясмык — 1701, бәрәңге — 2878 дис. 184516 баш терлек, ш.и. 44926 — мөгезле эре терлек, 27315 — ат, 79846 — сарык, 21086 дуңгыз асрала. ТАССРны районлаштыру барышында кантон терр-ясендә Әлки һәм Спас р-ннары барлыкка килә.




Чыг.: Статистический справочник по промышленности ТССР. К., 1924; Статистический справочник по сельскому хозяйству. К., 1925; Всесоюзная перепись населения 1926 года. М., 1928. Т. 3; 1929. Т. 9; Статистический ежегодник по Татарской Социалистической Советской Республике: В 5 вып. К., 1928–29; Всесоюзная школьная перепись 15 декабря 1927 года. М., 1930. Т. 1.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**СПАС МАНАРАСЫ́**, Казан Кремле комплексындагы төп күзәтү-үтеп йөрү манарасы (46,6 *м*), 16–18 йөзләр рус саклану-кирмән архит-расы истәлеге. Арх. И.Я.Постник җитәкчелегендәге Псков осталары тарафыннан 1556–66 елларда төзелә. Башта ак таштан, үтеп йөрү манарасы ике катлы, үтү юлы борылмалы була, төньяктан янкорма рәвешендә Псков архит-расы стилендә Спас капка өсте чиркәве төзелә. Ике катлы манараның



Спас манарасы. Казан. Архитекторы И.Я.Постник. 1556–66. Алгы планда – хәрби чиркәү кәшәнәсе. Архитектор Ф.Н.Малиновский. 1910. 20 йөз башы фоторәсеме.

23×23 *м* лы квадрат нигезе, 2,25 *м* калынлыктагы шомартылган ак таш диварлары, агачтан корылган чатыр түбәле күзәтү манарасы була. Кремльгә төнгә каршы С.м. аша керү юлы тимер рәшәткә һәм авыр капкалар б-н ябылган. 1694 елгы янгыннан соң реконструкция процессында аңа кирпечтән сигезкырлы ике ярус һәм чатыр өстәп коралар. 1774 тә Пугачёв гаскәрләре Кремльне камап тупка тотканда, өске 2 яңа ярус, чатыр җимерелә, чиркәү диварлары ишелә. 1780 елларда торгызыла. 1815 һәм 1842 елгы янгыннарда манарага зур зыян килә. 1857 дә аны тамырдан реконструкцияләү башлана. Үтеп йөрү юлы кабаттан туры итеп корыла, нәтиҗәдә, манара заманча итеп үзгәртелә. 1910 да көньяк фасадка псевдорус стилендә кирпечтән янкорма-кәшәнә төзиләр (1930 да сүтелә).

Спас капка өсте чиркәве башта приход карамагында була, 1720 дән, анда яшәүче



Спас манарасы. Казан. Архитекторы И.Я.Постник. 1556–66. Хәзерге күренеше.

халыкны Кремльдән чыгаргач, губерна хакимияте кулына күчә; 1836 да император Николай I Фәрманы б-н хәрби ведомство чиркәвенә әверелдерелә, приходны Казан хәрби частьлары тәшкил итә. 1918 дә ябыла.

20 йөз башында манараның аскы сигезкырлыгына механик сәгать урнаштырыла, 1963 тә нәфис кыңгырау тавышлы электр сәгатьләренә алыштырыла (инженер Б.М.*Галиев*), чатыр түбәсенә алтын йөгертелгән йолдыз (нурларының колачы 2,7 *м*; арх. С.С.Айдаров) куела. «Казан Кремле» музей-тыюлыгы составына керә.

*Әд.:* З а р и н с к и й П.Е. Краткая историческая записка о Казанской кремлёвской во имя Спасителя (военной) церкви в г.Казани. К., 1870; ш у л у к. Очерки древней Казани. К., 1877; А й д а р о в С.С. Архитектурное наследие Казани. К., 1978; О с т р о у м о в В.П. Казань. К., 1978; Памятники истории и культуры Казани. К., 1982.

*Х.Г.Надыйрова.*

**СПАС ӨЯЗЕ́**, 1802–1920 елларда Казан губернасында. Үзәге — Спас шәһәре (1781 дә өяз шәһәре статусын ала, 1796 да штат карамагында калдырыла, 1802 дән кабат өяз шәһәре). 1781 дә Казан наместниклыгы составына керә. 1796 да наместниклык губернага үзгәртелә, С.ө. юкка чыгарыла, 1802 дә кабат торгызыла. Губернаның көньяк өлешендә урнашкан. Көнбатыш һәм төньяк-көнбатышта Казан губернасының Тәтеш, төньякта — Лаеш, төньяк-көнчыгышта Чистай, көньяктан — Самара губернасының Ставрополь өязе б-н чиктәш. Идел һәм Кама елга бассейннары: Үтәк, Майна, Грязнуха, Бизнә, Еноталка, Тохталка, Раткулка, Салман, Нократ, Актай, Инча, Чекма, Чирмешән, Томба, Көрнәле, Кадыкудь, Курка, Чаллы, Мурасинка, Олы һәм Кече Чирмешән, Налатра, Елшанка, Бәрән, Лягушкино, Болак, Шонталы, Ямбердина, Юшимка, Ямышка, Искимерка, Коры елга, Курлянка, Олы Чаллы, Балыкчы, Тигәнәле, Олы Салман, Кудара, Миләш, Абзерка, Юхмачы һ.б. б-н юыла. Мәйданы — 5252,6 кв. чакрым (1897). Халкы — 175198 кеше (89525 ир-ат, 85673 хатын-кыз), шуларның 58,5% ы руслар, 30,2%ы татарлар, 72%ы чуашлар, 4,1% мордвалар (1897). 19 йөздә 3 станга, 14 во-




лостька, 5 земство участогына бүленә. 1904 кә кадәр 1 нче станга (үзәге — Өчкүл а.) — Гусиха, Жедяевка, Өчкүл, Ширбәт, Йорткүл волостьлары; 2 нче станга (Рамодан а.) — Левашёво, Мораса, Николо-Пичкас, Полянка, Рамодан волостьлары; 3 нче станга (Әхмәт а.) Базарлы Матак, Кузнечиха, Түбән Әлки, Успение, Юхмачы волостьлары керә. 1905 тән үз эченә 4 стан, 5 земство участогын, 14 волостьны ала. 1 нче станга (үзәге — Пичкас а., 1916 дан Спас ш.) — Ширбәт, Гусиха, Николо-Пичкас волостьлары; 2 нче станга (Рамодан авылы) — Полянка, Рамодан, Левашёво, Мораса; 3 нче станга (Кузнечиха) Түбән Әлки, Юхмачы, Базарлы Матак, Кузнечиха; 4 нче станга (Өчкүл) — Өчкүл, Йорткүл, Жедяевка волостьлары керә. 1915 тә Иске Бәрән волосте оеша.

Өяздә 46 авыл һәм 159 сала исәпләнә. Халкы игенчелек (солы, арыш, бодай, карабодай, җитен, киндер игелә), терлекчелек, умартачылык, бакчачылык, балыкчылык, известь яндыру, сәүдә, поташ з-длары өчен юка нарат мичкәләр җитештерү, он тарту кәсепчелеге һ.б., читкә китеп эшләү, сәүдә б-н шөгыльләнә. Өяздән икмәк, ярма, борчак, он, балык, атлар чыгарыла. Ефәк, йон, киҗе-мамык, киндер тукыма, табак-сабыт, агач һәм балчык савытлар, сумала, дегет һ.б. кертелә. Өяздә сәнәгать көчле үсеш алмый (19 йөз ахыры). 20 з-д һәм фабрика ш.и. поташ, селитра, май җитештерү, шәраб, ат (Левашёво), кирпеч з-длары; «Кавказ һәм Меркурий» пароходчылык җәмгыятенең механика з-ды; 1 су һәм 18 җил тегермәне эшли. 20 йөз башында өяздә 625 башлангыч халык, 614 чиркәү-приход мәктәбе, Изге Гурий борадәрлегенең 142 миссионерлык башлангыч мәктәбе, ике сыйныфлы шәһәр уч-щесе; 86 мәдрәсә һәм мәктәп (1916) исәпләнә. С.ө. терр-ясендә урта гасырлардагы Болгар шәһәре, Куралово, Әҗмәр, Войкино, Ямкино, Караваево, Пичкас һ.б. авыллар янындагы болгар шәһәрлекләре урнашкан. Өяз крәстияннәренең крепостнойлыкка каршы 1861 елгы чыгышлары (к. *Бизнә крәстияннәре кузгалышы*) б-н дә мәгълүм. 1920 дә ТАССР оешу барышында юкка чыгарыла; Жедяевка һәм Йорткүл волостеның күп кенә авылларыннан кала, С.ө. волостьлары ТАССРның Спас кантоны составына керә.

Чыг.: Материалы для географии и статистики России, собранные офицерами Генерального штаба: Казанская губерния. СПб., 1861; Памятная книжка Казанской губернии на 1863 год. К., 1862; Материалы для сравнительной оценки земельных угодий в уездах Казанской губернии. К., 1887; Адрес-календарь и справочная книжка Казанской губернии на 1916 год. К., 1916.

*Әд.:* Спасский Н.А. Очерки по родиноведению. Казанская губерния. К., 1912; Энциклопедия города Болгар и Спасского района. Болгар, 2014.

*Д.А.Мостафина.*

**СПАС РАЙОНЫ́**, ТРның көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. Мәйданы — 2022,1 $км^2$. 1 шәһәр һәм 16 авыл җирлеген, 46 торак пунктны берләштерә. Үзәге — *Болгар* шәһәре. 2015 елда 19855 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 66,5%, татарлар — 30%) яши. Шәһәр халкы — 8,3 мең, авыл халкы — 11861 кеше. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 $км^2$ га 10 кеше. 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязендә, 1920–30 да ТАССРның Спас кантонында. Оешкан вакытында С.р.на 1 шәһәр һәм 41 авыл советы, 95 торак пункт керә, аларда 52504 (руслар — 46231, татарлар — 4641, башка халыклар — 1632) кеше яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1935 нең 10 февралендә С.р.ның бер өлеше яңадан оештырылган *Кузнечиха районына* (1960 ның 28 октябрендә кире кайтарыла) бирелә. 1935 нең 1 апреленнән — Куйбышев р-ны итеп үзгәртелә. 1940 та районның мәйданы — 1762 $км^2$, халык саны — 49,4 мең кеше, 34 авыл советы, 101 торак пункт була. 1960 та район 1700,6 $км^2$ җир били, аңа 1 шәһәр һәм 11 авыл советы, 66 торак пункт керә. 1963 нең 1 февралендә ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, Куйбышев р-нына Әлки р-ны кушыла. Районның мәйданы — 3922 $км^2$, халык саны — 82,5 мең кеше, 1 шәһәр һәм 34 авыл советы, торак пунктлар саны 164 кә җитә. 1965 нең 12 гыйнварында ТАССРда адм.-терр. бүленеш үзгәрү нәтиҗәсендә, район терр-ясе — 2026 $км^2$, халык саны — 38,7 мең кеше, 14 авыл советы, торак пунктларның саны 75 кә кала. 1991 нең 4 октябреннән район хәзерге исемен йөртә.




С.р.ның рельефы — иңкүлекле тигезлек (биеклеге 60–70 *м*). Идел (Куйбышев сусаклагычы) һәм кушылдыклары Бизнә, Актай, Үтәк елгалары ага. Җирләре, башлыча, типик, селтесезләнгән һәм көлсуланган кара, соры һәм карасу-соры урман туфраклы. Терр-ясенең 9% ы — урманлык. Мергель, балчык, комташ, доломит, бут ташы, ташкүмер ятмалары бар. Саклаулы табигать истәлекләре: *Атаман күле, Исемсез күл, Чиста күл, Чуртан күле, Спас* табигать тыюлыгы. Район терр-ясе таш гасырдан алып урта гасырлардагы Алтын Урда чоры археол. истәлекләренә (*Болгар шәһәрлеге, Коминтерн комплексы, Бураково каберлеге, Маклашеевка комплексы, Танкеевка каберлеге, Суар шәһәрлеге*) бай. Сәнәгать пр-тиеләре Болгар шәһәрендә тупланган. Урман хуҗалыгы бар. Мөгезле эре терлек, дуңгыз, ат үрчетү алга киткән. А.х. җирләре — 108 мең *га*, ш.и. сөрүлекләр — 93,3 мең *га* (2009). Сабан бодае, көзге арыш, арпа, солы, тары, борчак үстерелә. 2015 тә С.р.нда 98 крәстиян-фермер хуҗалыгы, 2 зур а.х. инвесторы («Болгар-Арыш», «ВЗП-Болгар» АҖләре) эшли. Район терр-ясеннән Болгар–Базарлы Матак автомобиль юлы уза. Иделдәге Болгар пристане хезмәт күрсәтә. 35 гомуми белем бирү мәктәбе, ш.и. 1 мәктәп-балалар бакчасы, 8 башлангыч, 11 тулы булмаган урта, 15 урта (ш.и. 1 кадет) мәктәп, тармак технологиясе техникумы, балалар иҗат йорты, балалар сәнгать мәктәбе, балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе, 29 китапханә, 32 клуб; район үзәк хастаханәсе, Кузнечиха һәм Куралово авылларында дәвалау амбулаторияләре, 33 фельдшер-акушерлык пункты эшли. Татар һәм рус телләрендә «Яңа тормыш» — «Новая жизнь» г-талары нәшер ителә.

*Әд.:* Энциклопедия города Болгар и Спасского района. Болгар. 2014.

**СПАС РАЙОНЫ́**, *Түбән Новгород өлкәсенең* көньяк-көнчыгышында урнашкан. 1929 елда оештырыла. Мәйданы — 706,5 $км^2$. Үзәге — Спас авылы (Түбән Новгородтан 237 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 10202 кеше (2013), татарлар — 2009 кеше (2010). Татарлар, тупланып, Татар Моклокасы, Тукай, Бозлау, Ишавыл авылларында яшиләр. Беренче тапкыр бу авыллар 1609–13 елларда телгә алына. 1794 елгы мәгълүматларга караганда, татарлар саны: Татар Моклокасында — 742 (1916 да — 5513), Паршада — 132 (1155), Бозлауда — 336 (854), Ишавылда 312 (888) кеше. 19 йөз уртасында С.р. терр-ясендә 7 мәчет (ш.и. Татар Моклокасында — 2) була. Хәзерге вакытта районда Татар мәдәнияте үзәге (1990 еллар ахырыннан), үзешчән сәнгать коллективы һәм татар билбау көрәше өлкә федерациясе (Бозлау); Бозлау (1999 дан) һәм Татар Моклокасы (2002 дән) авылларында тарих музейлары эшли. Боз-

лау һәм Татар Моклокасы урта мәктәпләрендә, Тукай авылы тулы булмаган урта мәктәбендә, Ишавыл башлангыч мәктәбендә татар теле фән буларак өйрәнелә. Районда 8 мәчет (Ишавылда — 3, Татар Моклокасы һәм Бозлауда — 2 шәр, Тукайда — 1) эшли. С.р. терр-ясендә спутник антенналары аша «Татарстан — Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе тапшырулары күрсәтелә. Ел саен *Сабан туе*, билбау көрәше буенча ярышлар, Бозлау авылында татар җыры фестивале уздырыла. Арктиканы өйрәнүче, Төньяк полюс — 5 экспедициясендә катнашучы С.С.Абызов (Татар Моклокасы а.), самбо көрәше буенча СССРның атказанган спорт остасы З.Ә.*Умәров* (Татар Моклокасы а.), самбо көрәше буенча 8 тапкыр дөнья чемпионы Р.Х.Рәхмәтуллин (Ишавыл а.) С.р.нда туганнар.

*Әд.:* О р л о в А.М. Нижегородские татары: Этнические корни и исторические судьбы (очерки). Н.Новгород, 2001.

*Х.Ә.Габделкаюмов.*

**СПАС ЧИШМӘЛӘРЕ́**, табигать истәлеге. Бөгелмә р-ны Спас авылында. 1989 елда билгеләнә. Чишмәнең мәйданы 1 *га*, су саклаулы зона мәйданы 20 *га*. Су дебитының югары (80 *л/с* тан артык), матурлыгы һәм агымның көчле булуы б-н уникаль. Көньяк-көнбатыш экспозициянең текә сөзәклеге итәгеннән бәреп чыга. Чишмә суы Дим елгасына коючы



Спас чишмәләре.

кушылдык хасил итә. Яр буендагы тал һәм юкә утыртмалары гаҗәеп матур күренеш тудыра. Эчәргә яраклы су чыганагы буларак файдаланыла.

**СПАС-ПРЕОБРАЖЕ́НИЕ МОНАСТЫРЕ́**, Казандагы архит-ра истәлеге. Татарстан терр-ясендәге иң беренче монастырьларның берсе, 1918 елга кадәр Казан епархиясендә үзәк монастырь була. 1555–58 елларда архимандрит *Варсонофий* тарафыннан нигез салына. Казан Кремленең көньяк-көнбатыш өлешендә, Спас, Көньяк-Көнбатыш һәм Преображение манаралары арасында урнашкан. Монастырьның беренче корылмалары агачтан була, 1579 елгы янгыннан көчле зыян күрә. 1596–1601 дә янган чиркәү урынында таштан куб рәвешендәге 3 апсидалы, 3 нефлы, 6 баганалы, суганбашсыман 5 гөмбәзле Спас-Преображение соборы төзелә. 1596 да монастырь башлыгы корпусы һәм ашханә бинасы кушылган Никола Ратный чиркәве корыла. Алар собор б-н галерея булып берләшәләр. Шул ук елда янган храм урынында монастырь диварында таштан баштан ук приход чиркәве булган, бер гөмбәзле Киприан һәм Устина храмы төзелә (монастырьга 1764 тә беркетелә). 1670 тә монастырьның көнчыгыш өлешендә таштан Изге Варвара чиркәве б-н бергә квадрат рәвешендә чаң манарасы калкып чыга, 1855–62 дә аның урынында сәүдәгәр П.А.Прибытков акчасына 4 ярусլы чаң манарасы төзелә. 17 йөз ахыры — 18 йөз башында икешәр катлы өч борадәрлек корпусы күтәрелә. Спас манарасына кушылган урында монастырь башлыклары, сәүдәгәрләр, уку йортлары укытучылары, ш.и. П.Д.*Шестаков*, В.М.*Флоринский*, Х.Г.*Пашковский*, П.В.*Знаменский*, Н.Ф.*Катанов*лар җирләнгән зират була. Митрополит *Ефрем*, изгеләштерелгән *Иона һәм Нектарий* собор алтаре янындагы кәшәнәдә җирләнәләр. Төрле елларда монастырь настоятельләре булган монахлар — *Гермоген*, *Вениамин* (Пуцек-Григорович), *Платон* (Любарский), *Андрей* (Ухтомский), *Иоасаф* (Удалов). 1775–1830 да монастырьда — Казан архиерейлары резиденциясе, 1842–44 тә — *Казан руханилар академиясе*, 1898–1917 дә *Казан миссионерлык курслары* урнаша.

Монастырь 1918 нең 22 сентябрендә ябыла; совет чорында аның терр-ясендә хәрби часть урнаша, барлык храмнар, чаң манарасы, корпусларның өчтән ике өлеше сүтелә, зираттагы һәм кәшәнәдәге каберләр асфальт б-н тигезләнә. 1994 тә монастырь биләгән терр-я «Казан Кремле» тарихи-архит-ра һәм сәнгать музей-тыюлыгы карамагына тапшырыла, 1995 тән монастырь урнашкан җирдә археол. эзләнүләр һәм реставрация эшләре алып барыла, Ефрем, Иона һәм Нектарийның изге җәсәдләре *Петропавел соборына* күчерелә. Спас-Преображение соборының подвалы казыла (анда археол. музее бинасы урнашыр дип көтелә), 2004 тән Никола Ратный чиркәве торгызыла.

*Әд.:* Л е б е д е в Е.М. Спасский монастырь в Казани: Историческое описание. К., 1895; Е л д а ш е в А.М. Монастыри Казанского края: Очерки истории. К., 2004; ш у л у к. Казанский некрополь. К., 2009.

**СПАС СОБОРЫ́**, Алабугадагы архит-ра истәлеге. 1816 елда әүвәлге эклектика элементлары булган рус классицизмы стилендә төзелә, 1855–64 тә киңәйтелә, яңа чаң манарасы корыла. Шәһәр үзәгендә урнашкан, шәһәр төзүче доминанта булып тора. 1937 дә ябыла, склад итеп файдаланыла; интерьерындагы 1880 дә башкаланың күренекле рәссамнары В.В. һәм В.П.Верещагиннар һәм И.А.Осокин тарафыннан югары сәнгать дәрәҗәсендә тө-



Алабугадагы Спас соборы. 1808–11.

шерелгән дивар бизәкләре һәм бизәлеш сәнгатенең гүзәл истәлеге булган алтаре тулысынча юкка чыга. 2005–07 дә соборның тышкы ягы реставрацияләнә, эчке реставрация эшләре алып барыла. 1991 дә Покров чиркәве диндарлар җәмгыятенә тапшырыла, 2008 дә мөстәкыйль приход үзәге булып әверелә. Бер корылмага берләштерелгән өч өлештән тора: биш гөмбәзле җылы чиркәү, 1 катлы, 12 тәрәзәле озынча ашханә һәм 72 *м* биеклектәге биш ярусլы чаң манарасы. Штукатурланган кирпеч собор үзенең күләмле композициясе, үзенчәлекле биш гөмбәзе, чиркәү экстерьер һәм интерьерларында пилястралар рәвешендәге таш һәм акбурлы декоратив бизәкләрдә тоскан, ионик һәм коринф ордерларының органик кушылуы б-н кызыклы. Тоскан ордерлы колонналар һәм а́ркалы антаблемент файдаланылган монументаль портиклы ишеге булган собор коймасы да аерым кыйммәткә ия.

*Әд.:* Республика Татарстан: Православные памятники. К., 1998.

*Е.В.Липаков, Т.С.Чудинова.*

**СПА́ССКИЙ** Николай Николаевич (24.2.1896, Тамбов ш. — 24.10.1974, Казан), микробиолог, эпидемиолог, мед. фән. д-ры (1958), проф. (1959). Саратов ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1919), Тамбов бактериология ин-тында эшли, Үзәк Россия губерналарында тиф, ваба, паразитар авыруларга каршы көрәш чараларында катнаша. 1926 елдан Р.Кох ин-тында (Берлин) стажировка уза. 1928 дән Киев сан.-бактериол. ин-тында, бер үк вакытта Киев ГИДУВында укыту эшендә. 1937 дән Воронеж мед. ин-тында эпидемиол. һәм микробиол. каф. мөдире. 1940–70 елларда — Казан ГИДУВының микробиол., 1959 дан эпидемиол. кафедралары мөдире. Бөек Ватан сугышында катнаша, Төньяк флотның флагман эпидемиологы. Хезмәтләре түләмә, стафилококк, стрептококк, йогышлы эчәк авыруларын (ш.и. дизентерияне китереп чыгаручы Штуцер-Шмитц төре бактерияләрен) өйрәнүгә карый. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Экспериментальные материалы к вопросу о токсикозе при дизентерии, вызванной бактериями Штуцер-Шмитца. К., 1958; Токсигенные свойства дизентерийных бактерий. К., 1963.

*Әд.:* Николай Николаевич Спасский // Казан. мед. журн. 1975. № 4.

**СПЕКТР ПРИБОРЛАРЫ́**, матдә тарафыннан нурландырылган, йотылган яки чәчелгән яктылыкның спектраль составын матдәнең үзлекләрен, химик составын, нурланыш б-н бәйле физик процессларның характерын өйрәнү максатында сыйфат һәм микъдар ягыннан тикшерүдә (спектроскопия һәм спектраль анализ) кулланыла торган оптик җайланмалар. Мондый приборлар ярдәмендә ш.у. алдан бирелгән спектр составлы нурланыш алырга да мөмкин. С.п. фән-техниканың һәм сәнәгать җитештерүенең төрле тармакларында киң кулланыла.

С.п. ярдәмендә яктылык нурланышы спектрга бүленә (диспергирлана), спектраль сызыклар һәм участоклар теркәлә һәм аларның көче үлчәнә. С.п. яктырту, спектраль

һәм теркәү өлешләреннән тора. Аларның классификациясе оптик схемалардан (монохроматор, спектрограф һ.б.), визуаль (спектроскоп), фотографик (спектрограф), фотоэлектрик (спектрометр, спектрофотомер) теркәү элементларыннан, анализлау төреннән чыгып билгеләнә. Үлчәү процесслары тулысынча автоматлаштырылган приборларны спектроанализаторлар дип атыйлар. С.п.н төп техник һәм оптик характеристикалары: спектраль диапазоны (ультрашәмәхә, күренмә, инфракызыл), яктылык көче, почмакча һәм сызыкча дисперсиясе, ачыклый алу чиге буенча аерып йөртәләр. Хәзерге С.п.нда диспергирлау элементы ролен яссы һәм батынкы дифракция рәшәткәләре (ДР) үти. Яссы ДР кулланганда коллимирлаучы (параллель яктылык бәйләме алу өчен) һәм фокуслаучы объективлар кирәк. Батынкы ДР, турыдан-туры коллимирлау һәм фокуслау үзлекләренә ия булсалар да, сурәтне шактый ук бозып күрсәтәләр (аберрация). Аберрациясе төзәтелгән батынкы ДР куллану иң аз оптик элементлар ярдәмендә югары сыйфатлы спектрлар алу мөмкинлеге бирә (к. *Дифракцион оптика*).


Илдәге С.п. төзелешен үстерүдә *Гамәли оптика институты* (ГИПО), *Казан оптика-механика заводы* (КОМЗ), Үзәк «Фотон» КБ зур роль уйный. 1959 да Дәүләт оптика ин-ты (Ленинград), Үзәк машиналар төзү фәнни-тикшеренү ин-ты (Мәскәү), СССР ФАнең Кола ф-лы Поляр геофизика ин-ты (Мурманск ш.), СССР ФАнең Физика ин-ты (Мәскәү) һ.б.ның заказлары буенча ГИПО хезмәткәрләре фәнни тикшеренүләр өчен С.п. эшләүгә керешәләр. 1960 еллар уртасына сәнәгатьнең төрле тармакларына керүче завод лаб-яләренә С.п. җиһазларын эшләү башлана. Адсорбцион-атом спектрофотометрлары СА-2 һәм СА-10, спектрографлар ДФС-452 һәм ДФС-458 һ.б. С.п. КОМЗга һәм илнең башка з-дларына серияләп җитештерүгә тапшырыла. Заманча элементлар базасы (аберрацияләрне төзәтүче батынкы голограммалы ДР, диодлы линейкалар), кече габаритлы нурланыш чыганагы, идарә программалары системасы файдаланыла торган кече габаритлы автоматлаштырылган «Сириус» спектрографы иң яңа эшләнмә булып тора. С.п. төзүгә С.О.*Мирумянц*, Ю.С.Нагулин, Н.К.Павлычева, И.Е.Кит, С.С.Мурзиева, В.А.Чумакова һ.б. зур өлеш кертә. Татарстан галимнәренең казанышлары СССР ВДНХсы медальләре, хезмәт Кызыл Байрагы ордены (Ю.С.Нагулин), ТР Дәүләт бүләге (1998) б-н билгеләнә. Уйлап табуга 12 авторлык таныклыгы һәм патент заманча техник чаралар күрелүен дәлилли.

*Әд.:* Научно-производственное объединение «Государственный институт прикладной оптики». К., 1997. Ч. 1; П а в л ы ч е в а Н.К. Спектральные приборы с неклассическими дифракционными решётками. К., 2003.

*Н.К.Павлычева.*

**СПЕРА́НСКАЯ** (чын фамилиясе Штейн) Любовь Львовна (23.6.1918, Витебск ш., хәзер Белоруссия Респ-касы — 14.9.2010, Казан), сәхнә бизәүче рәссам, ТРның халык рәссамы (1998). 1936–41 елларда Ленинград ун-тында укый, ТАССРга эвакуацияләнә, 1945–53 тә Татар опера һәм балет театрында башкаручы-рәссам. 1949–72 дә Казан театр уч-щесендә укыта. Бер үк вакытта, 1953–57 һәм 1970–72 дә, Казан курчак театрында баш рәссам. 1953 тә Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый. Бөтенроссия театр эшлеклеләре җәмгыяте (1952), Рәссамнар берлеге әгъзасы (1968).

Татар опера һәм балет театрында С. классик балетлар бизи (декорацияләр һәм костюмнар), чорның характерлы үзенчәлекләрен, милли колоритны оста итеп чагылдыруга ирешә: Ф.Яруллинның «Шүрәле» (1945), Н.Җиһановның «Зөһрә» (1946), Р.М.Глиэрның



Л.Л. С п е р а н с к а я. «Бай шәһәр кешеләре киеме». Кәгазь. Акварель, гуашь. «Казан татарлары костюмы» китабыннан. 1972.

«Кызыл мәк» («Красный мак», 1950), Б.В.Асафьевның «Бакчасарай фонтаны» («Бахчисарайский фонтан», 1958), А.Аданның «Жизель» (1959), П.И.Чайковскийның «Аккош күле» («Лебединое озеро», 1967) балетлары. Бу театрда С. ш.у. П.И.Чайковскийның «Пики дамасы» («Пиковая дама», 1947), Д.Вердиның «Аида» (1948) һ.б. операларын, Казан курчак театрында — «Гүзәл Василиса» («Василиса Прекрасная», 1954), «Кар иле патшабикәсе» («Снежная королева», 1956), «Хәйләкәр Таҗи» (1957), «Канатлы ат» («Конёк-горбунок», 1957) спектакльләрен, Удмурт опера һәм балет театрында Г.М.Корепанов-Камскийның беренче милли «Италмас» (1978) балетын бизи. Петрозаводск, Сыктывкар, Чиләбе театрларында эшли. С.ның соңгы тапкыр бизәгән спектакле И.Штраусның «Зур вальс» («Большой вальс») әсәре буенча куелган спектакль була (Ижевск ш., 1984). Казан Зур драма театры өчен Тирсо де Молинның «Үз-үзенә көндәш» («Ревнивая к самой себе») әсәре буенча куелган спектакльгә костюмнар әзерли (1966, куючы-рәссам Э.Гельмс). Татар филармониясенең Җыр һәм бию ансамбле өчен сәхнә костюмнары эскизлары авторы (1957), үзешчән сәнгать коллективлары өчен костюмнар эшли, «Казан татарлары костюмы» («Костюмы казанских татар», 1972) китабына кергән авыл һәм шәһәр көнкүреше зарисовкаларын әзерли. 1960 елларда портретлар («Автопортрет», «П.Т.Сперанский портреты»), чәчәкле натюрмортлар, юмор б-н өретелгән сәхнә күренешләре («Димче килгәч») һ.б.ны иҗат итә. Шулай ук гамәли-бизәлеш сәнгате б-н дә шөгыльләнә (керәч вазалар, аш-су тәлинкәләре).



Л.Л.Сперанская.

Респ-ка (1951 дән), Мәскәүдә узган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы (1957) күргәзмәләрендә, ТАССРның театр рәссамнары (Мәскәү, 1977), зона — театр рәссамнары (Горький, Ульянов, Казан, 1960), «Зур Идел» (Казан, 1991; Түбән Новгород, 2003), бөтенсоюз — «Совет сәнгате мәктәбенә 50 ел» (Мәскәү-Ленинград, 1967) һәм кино, театр, телевидение рәссамнары хезмәтләре күргәзмәсендә (Мәскәү, 1967); бөтенроссия — «РСФСРның 16 автономияле республикасы» (Мәскәү, 1971), театр рәссамнарының халыкара күргәзмәсендә (Монреаль ш., 1967) катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда уздырыла (1998, 2008).

С. әсәрләре С.В.Образцов исем. Дәүләт акад. үзәк курчак театры каршындагы Курчак театрлары музеенда (Мәскәү), ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә саклана.

*Әд.:* С а т т а р о в а Н. Театральные художники Татарии // Советские художники театра и кино 1977/78. М., 1980; И л ь и н а М.Е. Художники театра // Татарстан. 2001. № 3; Д о н и н а Л.Н. Владеющая тайной ремесла // Казань. 2006. № 8/9.

*М.Е.Ильина.*



Л.Л.С п е р а н с к а я. «Бакчасарай фонтаны» балетына декорация эскизы. Картон. Темпера. 1958.

**СПЕРА́НСКИЙ** Алексей Дмитриевич (11.1.1888, Вятка губ. Уржум ш. — 23.7.1961, Мәскәү), патолог, медицина д-ры (1913), СССР ФА (1939), СССР МФА (1944) академигы, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1935), мед. хезмәте генерал-майоры. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1911), шунда ук, нормаль анатомия кафедрасында прозектор, аннары земство табибе булып эшли. 1914–19 елларда хәрби-мед. хезмәтендә. 1920 дән Иркутск ун-тының оператив хирургия һәм топографик анатомия каф. профессоры. 1923 тән Эксперименталь мед. ин-тында (Петроград, 1924 тән Ленинград), бер үк вакытта, 1926 дан, Хирургик

невропатология ин-тының эксперименталь бүлеген оештыручы һәм аның җитәкчесе, 1928 дән Эксперименталь мед. ин-тының патофизиол. бүлеге мөдире. 1934 тән Бөтенсоюз эксперименталь мед. ин-тының гомуми патология бүлеге мөдире (Мәскәү). Бөек Ватан сугышы елларында Совет Армиясе Баш сан. идарәсендә эшли. 1945 тән СССР МФАнең Гомуми һәм эксперименталь патология ин-ты директоры. 1954 тән СССР МФАнең Нормаль һәм патологик физиол. ин-тында гомуми патология бүлеге мөдире. Хезмәтләре төрле патологик процессларның барлыкка килүен, аларның үсеш алу, дәвам итү һәм тәмамлану механизмнарын өйрәнүгә карый. Авырулар барышында нерв системасының роле теориясен эшләгәне өчен, СССР Дәүләт бүләгенә лаек була (1943). СССР ФАнең И.П.Павлов исем. бүләге лауреаты (1937). Ике Ленин ордены, ике Кызыл Байрак ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нервная система в патологии. М.–Л., 1930; Элементы построения теории медицины. М.–Л., 1935.

*Әд.:* О с т р ы й О.Я. Развитие идей нервизма в системе исследований академика А.Д.Сперанского. Тб., 1958; П л е ц и т ы й Д.Ф. А.Д.Сперанский. М., 1967. *Н.Н.Максютова.*

**СПЕРА́НСКИЙ** Михаил Михайлович (1.1.1772, Мәскәү губ., Владимир өязе Черкутино а. — 11.2.1839, С.-Петербург), дәүләт эшлеклесе, хакыйкый яшерен советник (1827), граф (1839). Руханилар катлавыннан. Александр Невский руханилар семинариясен тәмамлый (С.-Петербург, 1791), шунда ук эшли (1792–97). 1797–1801 елларда Сенат генерал-прокуроры канцеляриясендә. 1803–07 дә Эчке эшләр министрлыгы департаменты директоры. 1807 дән император Александр I нең статс-секретаре. 1810–12 дә Россия Дәүләт Советы дәүләт секретаре. Реакцион дворяннар тарафыннан дәүләткә хыянәт итүдә гаепләнеп, 1812–16 да Түбән Новгород, Пермь шәһәрләрендә, Новгород губернасының Великополье авылында сөргендә була. 1816–19 да Пенза гражданнар губернаторы. 1819–21 дә Себер генерал-губернаторы, 1821 дән Дәүләт Советы әгъзасы. Бер үк вакытта, 1822–38 дә, Себер ком-ты әгъзасы, 1826 дан император Николай I канцеляриясендә 2 нче бүлек башлыгы. С. — дәүләт реформалары проектлары авторы. «Россия империясенең тулы законнар мәҗмугасы»н («Полное собрание законов Российской империи», 1–45 т., 1 нче җыентык, СПб., 1830), «Россия империясенең законнар мәҗмугасы»н («Свод законов Российской империи», 1–15 т., СПб., 1832) төзүгә һәм бастыруга җитәкчелек итә. Аларда 17 йөзнең 2 яртысында — 19 йөзнең 1 нче чирегендә Казан, Казан крае һәм Казан губернасы татарлары турында закон актлары тупланган. 1812 нең сентябрендә, 1819 ның маенда һәм 1821 нең февралендә С. Казанда була, Кремль, университет, гимназия һ.б. истәлекле урыннарны карап йөри. 1819–21 елгы «Көндәлеге»ндә («Дневник») Казан губернасы кыскача тасвирлана, губерна администрациясенә, университет профессорларына, сәүдәгәр һәм руханиларга бәяләмә бирелә. Казан ун-ты (1819), Казан ун-ты каршындагы Рус әдәбиятын сөючеләр җәмгыятенең (1819) шәрәфле әгъзасы. Изге Андрей Первозванный, Изге Александр Невский орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Руководство к познанию законов. СПб., 1845; Обозрение исторических сведений о своде законов. Од., 1889; План государственного преобразования. Введение к Уложению государственных законов. М., 1905; Проекты и записки. М.–Л., 1961.

*Әд.:* К о р ф М.М. Жизнь графа Сперанского: В 2 т. СПб., 1861; С е р е д о н и н С.М. Граф М.М.Сперанский: Очерк государственной деятельности. СПб., 1909; Ч и б и р я е в С.А. Великий русский реформатор: Жизнь, деятельность, политические взгляды М.М.Сперанского. М., 1989; Т о м с и н о в В.А. Светило российской бюрократии: Ист. портрет М.М.Сперанского. М., 1991. *Е.Б.Долгов.*

**СПЕРА́НСКИЙ** (чын фамилиясе Сенников) Пётр Тихонович (20.12.1890, Казан — 13.12.1964, шунда ук), театр рәссамы, сынчы, архитектор, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1945), ТАССРның халык рәссамы (1948). 1941 дә Казан сәнгать мәктәбен тәмамлый (Н.И.Фешин һәм П.П.Беньковта укый). «Сәйяр» труппасында (1915–17) һәм Казан опера театрында (1916–20) рәссам булып эшли, бер үк вакытта, артист буларак,



П.Т.Сперанский.
«Алтынчәч» балетына декорация эскизы. 1957.

сәхнәдә чыгыш ясый (драма студиясен тәмамлый). 1924 тә Казан архит-ра-техник ин-тының архит-ра бүлеген тәмамлый (хәзер Казан сәнгать уч-щесе). 1922–44 тә (бүленеп) — Татар акад. театрында, 1938–40 та — Бөтенсоюз а.х. күргәзмәсенең ТАССР павильонында (Мәскәү), 1939–64 тә Татар опера һәм балет театрында баш рәссам. 1930–42 дә — Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тында, 1943–64 тә Казан сәнгать уч-щесендә укыта. С. — *ТатАХРР* (1923), Архитекторлар берлеге (1935), Бөтенроссия театр эшлеклеләре җәмгыяте (1936), Рәссамнар берлеге (1936) әгъзасы.

С. — респ-када совет сәхнә бизәлеше сәнгатенә нигез салучыларның һәм осталарының берсе, сәхнә бизәлеше сәнгатенең реалистик мәктәбе традицияләре тарафдары. «Сәйяр» труппасында һәм Татар акад. театрында татар, рус, совет һәм чит ил авторларының әсәрләре буенча дистәләрчә драма спектакльләрен, ш.и. Г.Камалның «Банкрот» (1933, 1935, 1944) һәм «Беренче театр» (1915–16), Т.Гыйззәтнең «Җирсезләр»



П.Т.Сперанский.

(1922), «Наёмщик» (1928, 1931), У.Шекспирның «Король Лир» (1944, 1956), Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» (1940, 1952) пьесалары буенча куелган спектакльләрне бизи. Истә калырлык иҗади үзенчәлеккә ия, сәхнәнең фәзаи чикләрен хыялыйларга хас осталык б-н киңәйтеп, спектакльләрнең эмоциональ атмосферасына аваздаш декорацияләр әзерли, пейзаж күренешләрен җентекләп эшкәртеп һәм театр күренешләренең чынбарлыктагы хисләрен көчәйтеп, узган чорларның архит-расын, мәдәниятен һәм көнкүрешен кабаттан тергезә. Әлеге театрга талантлы рәссамнардан М.Г.Сутюшев, Р.М.Һибәтуллин, М.М.Абдуллинны җәлеп итә. Татар опера һәм балет театры спектакльләрен бизәгәндә күрелмә образларны муз. образларга оста буйсындыра, декорацияләр муз.-театраль күренешләр синтезының бер образы буларак кабул ителә (М.Глинканың «Иван Сусанин» (1951), П.Чайковскийның «Пики дамасы» («Пиковая дама», 1947, 1954), «Евгений Онегин» (1940, 1956), А.Бородинның «Кенәз Игорь» (1948), Н.Римский-Корсаковның «Шәһрезадә» (1955), Н.Җиһановның «Алтынчәч» (1943) опералары; Ф.Яруллинның «Шүрәле» (1945, 1953, 1957), Ә.Бакировның «Алтын тарак» (1957), Р.Гобәйдуллинның «Кисекбаш» (1958), Р.Глиэрның «Бакыр җайдак» («Медный всадник», 1963 балетлары). Татар халкының тарихын, сәнгатен һәм музыкасын тирәнтен белүе рәссамга милли опера һәм балетларга ачык буяулар б-н эшләнгән, истә калырлык декорацияләр тудырырга мөмкинлек бирә.

1920 еллар башыннан С. Казанда ленинчыл монументаль пропаганда планын тормышка ашыру эшенә кушылып китә, М.Вахитовка һәйкәл (1921), Арча кырындагы туганнар каберлеге (1925) проектларын, Кызылармиячеләр сарае өчен монументаль дивар бизәкләре эскизларын (1920–21) эшли, Мәскәүдә узган Бөтенсоюз а.х. күргәзмәсендәге ТАССР павильонын бизи (1939). С. элекке Гостиный двор (1933–35), «Динамо» (1934–35)



П.Т.Сперанский.
«Шүрәле» балетына декорация эскизы. 1957.

һәм «Хезмәт резервлары» (1936) стадионнары биналары, СССР ФАнең Казан ф-лы өчен элекке Ксения гимназиясен реконструкцияләү (1950), Н.Е.Ершов һәйкәле (1967, скульп. И.А.Новосёлов) һ.б. проектлар авторы. Монументаль-декоратив сәнгать өлкәсендә аның тарафыннан Татар акад. театры фойесында диварга плафон б-н бизәк төшерелә (1941), ул анда татар орнаменты үрнәкләреннән файдалана. Кавказ, Кырым, Идел ярлары, Казан күренешләреннән лирик пейзажлар (акварель, темпера) авторы («Рица күле», 1953; «Гагра. Парк», 1953; «Яңа Болак», «Төнге порт», икесе дә — 1959; «Идел яры. Ташлар», 1961; «Идел күренеше», 1964).

С. татар гамәли-бизәлеш сәнгате әсәрләрен туплый һәм өйрәнә, алардан күпсанлы рәсемнәр, ш.и. татар орнаменты күренешләрен ясый («Татар халык орнаменты» альбомы, 1948, 1953).

Респ-ка (1921 дән) күргәзмәләрендә, АХРРның 8 нче «СССР халыкларының тормышы һәм көнкүреше» күргәзмәсендә (Ленинград, 1926), Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә ТАССР сынлы сәнгате күргәзмәсендә (Мәскәү, 1957), зона — Идел буе театр рәссамнары (1960), «Зур Идел» (Куйбышев, 1964), бөтенроссия — театр һәм кино рәссамнары әсәрләре (Мәскәү, 1956), опера һәм балет театры рәссамнары әсәрләре (Мәскәү, 1964), бөтенсоюз — Бөек Октябрь революциясенең 40 еллыгына багышланган (Мәскәү, 1957–58), театр, кино һәм телевидение рәссамнары әсәрләре (Мәскәү, 1967) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда (1947, 1961, 1975–76), Мәскәүдә (1960) уздырыла.

Әсәрләре А.А.Бахрушин исем. Үзәк театр музеенда (Мәскәү), ТР Милли музеенда, ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, А.М.Горький әдәби-мемориаль музеенда (Казан), Әлмәттәге Картиналар галереясында саклана.

Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. С.ның Казанда 1957–64 тә яшәгән йортына мемориаль такта куела.

*Әд.:* Ц о й В. Пётр Тихонович Сперанский: Буклет. К., 1980; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Театральная энциклопедия. М., 1965. Т. 4.

*И.Е.Ильина.*

**СПИД**, кеше иммунодефициты вирусы — ВИЧ-инфекция йөртү сәбәпле, организмның иммун системасы зарарлану. ВИЧ Retroviridae семьялыгыннан Entriviridae ассемьялыгы, Retrovirus ыругына карый. 1983 елда табыла. Беренче тапкыр 1988 дә (АКШ) тасвирлана. Вирусның 2 тибы билгеле. ВИЧ-1 (HIY-1) — СПИД китереп чыгаручы ВИЧ-инфекциянең төп сәбәпчесе, элегрәк Төньяк һәм Көньяк Америкада, Европада, Азиядә, Үзәк, Көньяк һәм Көнчыгыш Африкада HTLY-111 яки LAy буларак билгеле була. ВИЧ-2 (HIY-2) — вирулентлыгы азрак вирус, СПИДның типик билгеләрен китереп чыгармый диярлек. Көнбатыш Африкада таралган СПИДның сәбәпчесе. ВИЧ түбән темп-раларга чыдам, –56°С та 30 *мин.* эчендә үлә, ш.у. этанол, эфир, ацетон, гадәти дезинфекцияләүче матдәләр тәэсирендә тиз юк ителә. Канда һәм башка биол. тирәлектә яшәүгә сәләтлелеге гадәти шартларда берничә тәүлек буена саклана. ВИЧ-инфекциягә бирешүчәнлек гомуми характерда була. Вирус җенси, парэнтераль вертикаль юл б-н (анадан яралгыга), ана сөте аша йога. Авыру акрынлап көчәя, билгеләре 3–6 айдан соң гына беленә (канда антитәнчекләр табыла). Организмда (лимфоцитларда, Т-хелперларда, моноцитларда, макрофагларда, нерв тукымасы күзәнәкләрендә) озак еллар буена ВИЧ саклану (10–12 ел буе ВИЧ-инфекцияне симптомнарсыз йөртү) организмның иммун системасы зарарлануга — СПИДка китерә. Авыру кеше әгъзалар һәм системаларның вирус яки икенчел йогышлы авырулар — оппортунистик инфекцияләр (кандидоз, фурункулёз, герпес, үпкә ялкынсыну, токсоплазмоз, менингит, сепсис һ.б.), ш.у. яман шеш аркасында зарарлануы нәтиҗәсендә вафат була. ВИЧның мөһим үзлеген организм иясенең күзәнәк геномы б-н интеграцияләнү тәшкил итә, шул үзлеге вирусны барча төр дару матдәләре тәэсиреннән саклый. Вирус интеграциясен һәм аның репликациясен вирусның «кайтма транскриптаза» ферменты контрольдә тота. Дәвалау вирусның үрчү процессын туктатуга юнәлдерелә. Кайтма транскриптаза һәм протеаза ингибиторлары репликациясенә тәэсир итүче препарат комбинацияләре кулланыла.

ТРда 2014 елга кадәр 16723 ВИЧ-инфекция очрагы теркәлә (2001 гә — 1421), таралыш күрсәткече 100 мең кешегә 428,4 очрак тәшкил итә. 1989 елның 14 августында ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында махсус сәламәтлек саклау учреждениесе — *Республика СПИДка каршы профилактика үзәге* оеша.

*Әд.:* Т у р ь я н о в М.Х., Ц а р е г о р о д ц е в А.Д., Л о б з и н Ю.В. Инфекционные болезни. М., 1998; Краткая медицинская энциклопедия. М., 1999. Т. 1; Справочник-путеводитель практикующего врача. 2000 болезней: от А до Я. М., 1999; ВИЧ-инфекция: клиника, диагностика, лечение. М., 2000.

*Д.Р.Нуретдинова.*

**СПИН-РӘШӘТКӘ́ РЕЛАКСА́ЦИЯСЕ**, парамагнетикта магнитлы кисәкчекләр системасы (спиннар системасы) б-н кристаллик рәшәткә (фонон системасы) арасында җылылык тигезләнеше урнашу. Сыеклыкларда «рәшәткә» сыйфатында спин системасын әйләндереп алган тирәлек алына. С.-р.р. вакыты — парамагнетик материалны гамәли куллану юнәлешен (мәс., квант электроникасы приборларында эшче матдә сыйфатында) билгеләүче мөһим параметр. Каты җисемнәрдә С.-р.р.нә китерә торган спин һәм рәшәткә бәйләнешен рәшәткә тирбәнешләренең парамагнетик кисәкчекләрнең үзара тәэсир итешүләрен модульләштерүе (Валлер механизмы) яисә парамагнетик кисәкчекләрдә кристаллик электр кыры модульләшү (Кронинг-Ван Флек механизмы) тудыра. Иң гади релаксация процесслары спинның бер энергетик дәрәҗәдән икенчесенә фононнар — рәшәткә тирбәнешләре квантлары нурландырып (йотып) күчүеннән гыйбарәт; туры (бер фононлы), Раман (кушма чәчелү тибындагы ике фононлы) процессларын, резонанслы флуоресценция тибындагы ике баскычлы процессларны аерып йөртәләр. С.-р.р. вакытының темп-рага, тышкы магнит кырына яки парамагнетик кисәкчекләр концентрациясенә бәйлелеге релаксациянең теге яки бу механизмының, релаксация процесслары типларының өстенлек итүен ачыклау мөмкинлеге бирә.

С.-р.р. еш кына спин һәм (яки) фонон системасының бериш булмавы аркасында катлаулана, бу очракта релаксацияне сурәтләү өчен вакыт параметры гына җитми: мәс., магнитлы кисәкчекләрнең файдалы спины S>1/2 яки спин системасында рәшәткә б-н төрлечә бәйләнгән берничә типтагы кисәкчекләр булган очраклар һ.б. Туры һәм ике баскычлы релаксация процессларында рәшәткәнең билгеле бер ешлыклардагы тирбәнешләре генә катнаша. Мондый тирбәнешләрнең рәшәткәнең калган өлеше б-н бәйләнеше көчсез булганда, «фононлы тар муентык» дип йөртелә торган күренешләр күзәтелә. Казанда С.-р.р.н теоретик һәм тәҗрибәдә тикшерүләр 1955 тә С.А.Альтшулер җитәкчелегендә башланып китә. Эремәләрдә парамагнетик комплексларның Альтшулер-Вәлиев механизмы, кристалларда С.-р.р.нең *Орбах-Әминов процессы* танылу ала.

*Әд.:* А л ь т ш у л е р С.А., К о з ы р е в Б.М. Электронный парамагнитный резонанс соединений элементов промежуточных групп. М., 1972.

*Л.К.Әминов.*

**СПИННАРНЫ́Ң ПОЛЯРЛАШУЫ́**, кисәкчекләрнең спин моментларының билгеләнгән юнәлешкә карата ориентлашуы һәм (яки) спиннарның үзара ориентлашуында тәртипкә салынганлык. С.п. күп кенә физик күренешләрдә мөһим роль уйный. Аерым алганда, электрон спиннарның диполь полярлашуы (даими магнит кырына карата ориентлашуы) — *электрон-парамагнетик резонанс* (ЭПР) сигналларының, төш спиннарының диполь полярлашуы *төшнең магнит резонансы* (ТМР) сигналларының көчен билгели. Спиннарның үзара тезелүе ЭПР һәм ТМР спектрларының формасына көчле тәэсир ясый. Даими, мәс., 100 *милли Тесла* индукцияле магнит кырына урнаштырылган парамагнетик матдәдә бүлмә темп-расындагы электрон һәм төш спиннарының тигезләнешле диполь С.п. тиңдәшле рәвештә $10^3$ һәм $10^6$ тәртибендәге зурлыкка тигез. Тышкы магнит кырына карата спиннарның тулысынча тезелүе вакытында С.п. берәмлеккә тигез була, ә ЭПР һәм ТМР сигналларының көче (сизгерлеге) тиңдәшле рәвештә $10^3$ һәм $10^6$ тапкыр арта. ЭПР һәм ТМР ысулларының сизгерлеген тулысынча күтәрү өчен, С.п.ның төрле юллары кулланыла: оптик полярлашу, төш спиннарының Оверхаузер эффекты буенча динамик полярлашуы (ТДП), электрон һәм төш спиннарының химик полярлашуы (ЭХП һәм ТХП) һ.б. (мәс., төш реакцияләре барышында туган мезоннарда иң зур С.п. күзәтелә). Татарстанда С.п. өлкәсендә тикшеренүләр 1960 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы ин-тларында башланып китә: Физика-техника ин-тында хромилның этиленгли-

кольле комплексларында ТДПның иң зур эффектына ирешелә (Б.М.Козырев, Н.С.Гарифьянов, В.Н.Федотов), Органик һәм физик химия ин-тында фосфорның ТХП буенча беренче тәҗрибәләр үткәрелә (А.В.Ильясов, Я.А.Левин, Э.И.Гольдфарб, Д.Г.Победимский, Й.Ю.Сәмитов). ЭХП һәм ТХП буенча эшләр РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында алып барыла: ярсынган триплет молекулаларының спин бәйләнешле үзара аннигиляциясе нәтиҗәсендә электрон спиннарның поляризациясе теоретик фаразлана һәм беренче тапкыр тәҗрибәләр б-н раслана; конденсат тирәлекләрнең структураларын һәм молекуляр динамикасын билгеләүдә кулланыла торган мюонлы спин кайтавазы күренеше тикшерелә (С.А.Моисеев, Н.М.Сөләйманов һ.б.).

Электроннарда С.п.н өйрәнү хәзерге заман электроникасында яңа юнәлеш — спинтроника үсеше б-н бәйле. Спинтроника өлкәсендә приборларның эше С.п.н күчерү б-н билгеләнә, шул ук вакытта электрон приборларның эшен электроннар корылмасын күчерү билгели. Спинтроникада кулланылыш табу мөмкинчелеге булган ферромагнетиклардан, үтә үткәргечләрдән, антиферромагнетиклардан торучы күпкатлы структураларны тикшерү эшләре РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында (И.А.Гарифуллин) һәм Казан ун-тында (Л.Р.Таһиров) алып барыла.

*Әд.:* Федотов В.Н. Эффект Оверхаузера в жидких растворах комплексных соединений $Cr^{5+}$ и $Mo^{5+}$ // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1967. Т. 53; Динамическая поляризация ядер P31, индуцированная химическими реакциями // Изв. АН СССР. Сер. хим. 1970. № 7; Моисеев С.А., Сулейманов Н.М. Мюонное спиновое эхо // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1996. Т. 64; Эффект близости в системе Fe-Cr-V-Cr-Fe // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 2004. Т. 80; Spin Polarization and Magnetic Effects in Radical Reactions. Amst., 1984; Salikhov K.M. Mechanism of the Excited Triplet States Electron Spin Polarization caused by the mutual annihilation of triplet states // Applied Magnetic Resonance. 2004. Т. 26.

*К.М.Салихов.*

**СПИРИДО́НОВА** Вера Михайловна (15.3.1937, Саранск ш.), пианист, педагог, музыка белгече, сәнгать фән. канд. (1975), проф. (1993), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1988), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2008). 1959 елда Казан консерваториясен (В.Г.*Апресов* классы) тәмамлый. 1959–63 тә — Саранск музыка уч-щесендә, 1964 тән Казан консерваториясендә укыта. Тикшеренүләр өлкәсе — Татарстанның фортепиано сәнгате, фортепианода уйнау һәм пед. М.Ә.Мозаффаров, Н.Г.Җиһанов, Р.М.Яхин, А.З.Монасыйповларның фортепиано өчен язылган әсәрләренең тулы җыентыгын һәм татар фортепиано музыкасының башка басмаларын төзүче һәм аларның мөхәррире. 1995–2002 дә, лекция уку өчен, муз.-пед. форумнарга һәм Австрия, Греция, Дания, Италия, Польша, Финляндия, Франция, Чехия, Швециядә узган халыкара пианистлар конкурсларында жюри эшендә катнашу өчен чакырыла. Пианизм теориясе һәм тарихы, ш.у. фортепианода уйнарга өйрәтү методикасы белгече.

Хезм.: Исполнительный и методический анализ фортепианного произведения. М., 1984; Исполнительские указания Моцарта и редакции его сонат. К., 1988; Инвенции и симфонии Баха в педагогическом репертуаре. К., 1990; Казанская пианистическая школа и её истоки. К., 1996; О фортепианно-исполнительском интонировании. К., 2005; Очерки по истории фортепианного образования и исполнительства в Казани. К., 2008.

*Әд.:* Кантор Г.М. Музыковеды Казани. К., 2000.

**СПИРИДО́НОВА** Евгения Васильевна (6.1.1908, Казан губ. Лаеш ш. — 15.5.1975, Казан), икътисадчы, икътисад фән. канд. (1959). 1930 елда Көнчыгыш пед. ин-тын (Казан) тәмамлаганнан соң, Казан ФЗӨ һәм техникумнарында иҗтимагый фәннәр һәм политэкономия укытучысы булып эшли. 1938 дән Казан авиация ин-тында, марксизм-ленинизм каф. мөдире (1940–46), политэкономия кафедрасын оештыручы һәм аның мөдире (1946). «Икътисади сәясәт һәм Пётр I нең икътисади карашлары» («Экономическая политика и экономические взгляды Петра I», М., 1952) монографиясе авторы. 2003 тән Казан техник ун-тында ел саен халыкара фәнни-гамәли конференцияләр үткәрелә, С. хөрмәтенә алар Спиридонова укулары дип атала; галимнең тууына 100 ел тулуга багышланган конференция (2008) кысаларында ун-тта мемориаль такта ачыла. Медальләр, ТАССР ЮС Президиумының ике Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Газизуллин Ф.Г. Слово о творческом пути Спиридоновой Е.В. // Проблемы современной экономики. 2003. № 1; Хадиуллина Г.Н. Ещё раз о творческом пути Евгении Васильевны Спиридоновой // Актуальные проблемы современной экономики России. 2 Спиридоновские чтения: Сб. материалов междунар. науч.-практ. конф. К., 2004.

*Р.К.Мәҗитова.*

**СПИРИДО́НОВКА** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 37 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 198 кеше (мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү. 1750 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту, Уральск шәһәреннән тозлы балык ташу б-н шөгыльләнә. 1883 елгы мәгълүматларга караганда, С.да күн з-ды һәм 10 вак-төякләр кибете эшли. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Михаил Архангел чиркәве (1889–1902 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство һәм чиркәү-приход мәктәбе, земство почта станциясе, 2 су тегермәне була; сишәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3907 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Спиридоновка волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 617, 1883 тә — 1205, 1889 да — 1437, 1897 дә — 1720, 1900 дә — 1715, 1910 да — 2387, 1920 дә — 2252, 1926 да — 2208, 1938 дә — 1320, 1949 да — 934, 1958 дә — 1070, 1970 тә — 767, 1979 да — 549, 1989 да — 311, 2002 дә — 237 кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**СПИРИДО́НОВКА БИ́ТУМЛЫ ТОКЫМНА́Р ЧЫГАНАГЫ́**. Лениногорск р-ның Спиридоновка авылыннан 0,5 *км* төньяк-көнчыгыштарак. 1978–79 елда ачыла, 1983–86 да җентекләп тикшерелә. Җиңелчә битум сеңгән комташлар битумлы токымнар булып тора; Пермь системасы Казан ярусының түбән катламына туры килә. Файдалы катламның калынлыгы 4,5–15,2 *м*, уртача — 8,9 *м*. Ачылма токымнарның уртача калынлыгы 7,4 *м*, комташ һәм известьташ катламнары булган балчыксыл токымнардан тора. Токымнарның битум б-н туенганлыгы 1,4–8,4% тәшкил итә. Нигездә, битумнар мальталар классына, сирәк кенә — асфальт һәм оксидлашкан югары үзле нефтьләргә карый. Аларны асфальт-бетон кушылмасының минераль өлеше компоненты буларак куллану күзәнәкле 1 һәм 2 нче маркалы асфальт-бетон алырга мөмкинлек бирә. 1987–2001 дә үзләштерелә. Хәзер чыганакның 480,7 мең $м^3$ запаслары ТР җир асты байлыкларының бүленмәгән фондында исәпләнә.

*Әд.:* Геология и освоение залежей природных битумов Республики Татарстан. К., 2007.

*В.М.Морадымова.*

**СПИРТ ҺӘМ ЛИКЁР-АРАКЫ́ ҖИТЕШТЕРҮ́ СӘНӘГАТЕ́**, азык-төлек җитештерү сәнәгатенең азык чималыннан (бәрәңге, ашлык) этил чимал спирты һәм спирт-ректификат, ликёр-аракы, шәраб һ.б. төрле продукция җитештерү тармагы. Респ-ка пр-тиеләре тарафыннан РФдә эшләнүче спиртның 4% ы һәм аракының 10% ы җитештерелә (2013). Татарстанда С.һ.л.-а.җ.с. — РФдә иң эре алкоголь продукциясе җитештерүче: составында 7 ф-л, ш.и. Мамадыш, Тәрнәс (Нурлат р-ны, консервациядә), Усад (Биектау р-ны) спирт з-длары, *Бөгелмә ликёр-аракы заводы* (консервациядә), *Казан ликёр-аракы заводы*, Минзәлә, Түбән Кама, Усад ликёр-аракы з-длары, *Чистай ликёр-аракы заводы*, «Казанский» шәраб з-ды булган «Татспиртпром» АҖдән гыйбарәт. 2010 нан Буа спирт з-ды «Русский стандарт» корпорациясенә керә. Тармакта эшләүчеләр саны 2 мең кеше.

Казан төбәгендә беренче вак аракы з-длары 17 йөзнең 2 нче яртысында барлыкка килә (Чабаксар һәм Ядрин өязләрендә 3 казна аракы з-ды эшләве турында мәгълүматлар бар). 1738 елда граф И.И.Воронцов тарафыннан 5 нче Шомбыт аракы з-ды (Мамадыш өязе) нигезләнә, анда 22 кеше эшли, елга 3 мең чиләк чимал спирты җитештерелә (1913 тә А.Я.Лихачёв милкенә күчә; эшләүчеләр саны 40 кешегә, куәте 34 мең чиләкка җитә). 19 йөз ахырында — 24, 1913 тә — 38, ш.и. чиктәш Вятка губернасында — 2 (Алабуга өязе), Самара губернасында — 5 (Бөгелмә өязе), Сембер губернасында — 1 (Буа өязе), Уфа губернасында 5 (Минзәлә өязе) спирт пр-тиесе исәпләнә. Алар дворяннар, сәүдәгәрләр, алпавытлар милкендә була. Кагыйдә буларак, пр-тиеләр чимал чыганакла-

ры янында урнашалар, аларда кул хезмәте өстенлек итә, аз куәтле (10–20 *ат көче*) пар двигательләре, ягулык сыйфатында башлыча утын, өлешчә торф файдаланыла.

1913 тә эшләүчеләрнең гомуми саны 1400 ләп кеше тәшкил итә, чимал спирты — 1459 мең чиләк, ликёр-аракы эшләнмәләре (тулы булмаган мәгълүматлар буенча) — 1 млн. чиләк чамасы, чүпрә 12,8 мең пот күләмендә җитештерелә. Иң эре пр-тиеләр исәбенә Д.М.Вараксинның Казандагы ликёр-аракы (1863 тә нигезләнә, 158 кеше; 621 мең чиләк), Н.И.Щербаковның Мамадыштагы (1883, 60 кеше; 82,7 чиләк), В.Г.Стахеевның 12 нче Петровский (1896, 46 кеше; 179 мең чиләк), В.П.Сергеевның 23 нче Троицкий (1903, 16 кеше; 126 мең чиләк, икесе дә Уфа губернасы Минзәлә өязендә), И.В.Александровның Казандагы (1900, 29 кеше; 200 мең чиләк) аракы з-длары керә.

Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышлары елларында казна аракы сәүдәсе тыела. 1917 дә 6 аракы з-дының эшчәнлеге туктала (яналар һәм таркатылалар), калганнары национализацияләнә (1918–20), Татарстан ХКС карамагындагы 13 завод продукция чыгаруны дәвам итә. 1922 дә «Татспирт» берләшмәсе оештырыла, аның составына 7 аракы (спирт), 2 спирт-аракы (Казанда һәм Бөгелмәдә), 1 чүпрә-аракы з-длары керә. 1925 тә эшләүчеләр саны 150 кешедән артмый, чимал спирты — 425 мең, алкоголь продукциясе 225 мең чиләк күләмендә җитештерелә. Алдагы елларда С.һ.л.-а.җ.с. динамикалы үсеш кичерә. 1940 та 15 спирт (аларның 5 сендә ректификация бүлекләре, 1 сендә аракы цехы була) һәм 5 аракы з-ды исәпләнә, аларда 805 кеше эшли, 1,8 млн. *дал* шартлы чимал спирты (ш.и. ректификат), 1,6 млн. *дал* аракы һәм аракы эшләнмәләре, 49 мең *дал* йөзем шәрабы җитештерелә. Бөек Ватан сугышы елларында сәнәгать пр-тиеләре, башлыча, фронт ихтыяҗлары өчен эшли. 1940–44 тә продукция чыгару 2,9 тапкыр кими. 1960 елларда технологияләрне камилләштерү һәм С.һ.л.-а.җ.с.нең матди-техник базасын ныгыту чаралары эшләнә.

1970 кә, 1960 ел б-н чагыштырганда, аракы һәм аракы эшләнмәләре җитештерү 1,9 тапкыр, йөзем шәрабы эшләү 3,4 тапкыр арта, тиңдәшле рәвештә 3335 мең һәм 2553 *дал* тәшкил итә. 1975 тә Казан ликёр-аракы з-ды файдалануга тапшырыла. 1976–80 дә барлык пр-тиеләр (8 спирт һәм 4 ликёр-аракы з-ды) С.һ.л.-а.җ.с.нең «Казспиртобъединение» ЖБ (1980 нән — «Татспиртпром» ЖБ) составына керә. 1984 тә 4333 мең *дал* аракы һәм аракы эшләнмәләре, 4986 мең *дал* йөзем шәрабы җитештерелә. Продукциянең сыйфаты яхшыра, ассортименты киңәя, аракының «Столичная», «Пшеничная», «Посольская», «Сибирская», «Золотое кольцо» маркалары, көчле ачы «Старка», «Перцовка», «Зубровка», «Петровская», «Зверобой», аз градуслы ачы «Листопад», «Стрелецкая», «Имбирная», «Любительская», татлы «Яблочный пунш», «Сливянка», «Вишенка», «Рябиновая на коньяке» төнәтмәләре һ.б., «Вишнёвый», «Крем яблочный», «Абрикосовый», «Лимонный» һ.б.ш. ликёрлар барлыкка килә.

Эчкечелеккә каршы кампания вакытында (1986–91) Гребени, Кыят, Куралово спирт з-длары бетерелә, Яңа Троицкий, Беренче Май, Петровский, Төрнәс спирт з-длары, Минзәлә ликёр-аракы з-ды, «Казанский» шәраб з-ды мальтоза патокасы, крахмал, кесәл, азык чүпрәсе, җиләк-җимеш, яшелчә консервлары һ.б. эшләүгә үзгәртеп корыла. Нәтиҗәдә, 1984 ел б-н чагыштырганда, 1990 да аракы һәм аракы эшләнмәләре җитештерү 33,6% ка, йөзем шәрабы чыгару 3,3 тапкыр кими. Алкоголь продукциясенә дәүләт монополиясе бетерелгәннән соң (1992), ТРда бу юнәлештәге 10 хосусый пр-тие оеша (2006 га кадәр эшлиләр).

1997 дә С.һ.л.-а.җ.с.ндә дәүләт монополиясе урнаштырыла, «Татспиртпром» ЖБ җирлегендә алкоголь продукциясе җитештерүне, сатуны һәм аның сыйфатын контрольдә тотучы бердәм оешма — «Татспиртпром» ЖБ дәүләт унитар пр-тиесе (2004 тән — АЖ) төзелә. Тармак пр-тиеләре аның ф-лларына әверелә. Барлык пр-тиеләрдә тирән реконструкция уздырыла, алар техник яктан яңартып коралландырыла, дөнья стандартларына туры китереп җитештерү куәтләре модернизацияләнә, алдынгы ресурслар саклау технологияләре нигезендә көндәшлеккә сәләтле продукция чыгару өчен шартлар тудырыла. Нәтиҗәдә, 2000 дә 3366 мең *дал* спирт, 8734 мең *дал* аракы һәм аракы эшләнмәләре, ягъни, 1990 ел б-н чагыштырганда, 1,8 һәм 2,7 тапкырга күбрәк җитештерелә. 2005 тән консервантсыз натураль «тыныч» һәм күбекләнүчән шәраблар, коньяк, ш.у. аз градуслы коктейльләр эшләнә. Продукция ассортименты 70 исемдә. Кайбер пр-тиеләр (Буа, Төрнәс, Усад спирт з-длары) ашлыкны түбән темп-рада (85–90°С) пешерү ысулын үзләштерәләр, бу спирт сыйфатын яхшырту мөмкинлеге бирә. Усад спирт з-дында брага-ректификация җайланмасы өчен автомат идарә системалары кулланылышка кертелә, Усад з-дында ашлык әзерләү автоматлаштырыла. Александровка спирт з-ды ш.у. сыекландырылган азык углекислотасы эшләп чыгара. 2000 дә «Казанский» шәраб з-ды яңадан корыла, анда куәте елга 600 мең *дал* продукция җитештерерлек Италия җиһазлары урнаштырыла. Техник җиһазланыш дәрәҗәсе буенча пр-тие РФдә иң яхшылардан санала, ул 20 дән артык исемдә продукция — «тыныч» шәраблар (елга 300 мең *дал*), күбекләнүчән шәраблар (2 млн. шешә), аз алкогольле эчемлекләр (250 мең *дал*) җитештерә.

2003 тә Европада иң эре пр-тиеләрнең берсе, РФдә тиңе булмаган куәтле, ашлыктан тәүлеккә 6 мең *дал* югары сыйфатлы этанол эшләп чыгарырга сәләтле Буа спирт з-ды файдалануга тапшырыла. Өзлексез ачытуда һәм чимал спиртын ректификацияләүдә ресурслар саклау технологиясе кулланыла. 2012 дә Усад ликёр-аракы з-ды оештырыла. 2013–14 тә Мамадыш спирт з-ды тамырдан модернизацияләнә, Усад спирт з-дының яңа комплексы төзелә.

ТР ликёр-аракы з-длары продукциясе гади һәм төрле конфигурацияле савытларда (50 *мг* нан 5 *л* га кадәрге 25 тән артык үрнәктә) сатыла. Мамадыш спирт з-дыннан (салат ашлыгы б-н эшли) тыш барлык пр-тиеләрдә ферментлы технология файдаланыла. Усад спирт, Казан һәм Чистай ликёр-аракы з-дларында аракы көмеш тузаны сиптерелгән кокос күмере (көмешле фильтрлау) кулланып чистартыла, Бөгелмә ликёр-аракы з-дында сөт б-н эшкәртелә.

2013 тә җитештерелгән продукция (мең *дал*): азык-төлек чималыннан эшләнгән этил спирты — 3423,4, аракы һәм ликёр-аракы эшләнмәләре — 4556, шәраблар, шәраб эчемлекләре һәм шампан шәрабы — 52, коньяк — 5,7. Спирты аерып алынган бардадан 15 мең *т* коры гранулалы барда, 8 мең *т* коры азык чүпрәсе эшләнә.

Ректификацияләнгән этил спирты җитештерүдә чимал сыйфатында җирле хуҗалыклардан китерелгән ашлык, ликёр-аракы продукциясе чыгаруда Татарстанда эшләнгән «Люкс», «Альфа» категорияле спирт, шунда ук җитештерелгән шикәр, бал, респ-када үскән җиләк-җимешләр, шифалы үләннәр һ.б. кулланыла. Йөзем-шәраб материаллары Краснодар краеннан, Ленинград өлкәсенең Выборг шәраб терминалыннан, Италия, Румыния, Украинадан, ачы борыч Һиндстаннан, ферментлар Даниядән, каймак Нидерландтан, продукция тутыру өчен шешәләр Италия, Франция, Чехиядән сатып алына; көмешле фильтрлау җайланмалары «Технофильтр» ФҖБдән (Владимир ш.) китерелә.

Заводларның техник һәм технол. җиһазлары алкоголь җитештерүнең заманча таләпләренә туры килә; бизнес-процесслар халыкара ISO 9001:2001 стандартлары буенча сертификатланган. «Татспиртпром» АҖ Бөтенроссия сыра һәм алкогольсез эчемлекләр җитештерү сәнәгате фәнни-тикшеренү ин-ты (Мәскәү) б-н хезмәттәшлек итә, аның эшләнмәләрен файдалана. 1998 дән җирле («Татспиртпром») сыйфат стандарты да гамәлгә кертелә. Җитештерелүче спиртлар составында альдегидлар һәм катлаулы эфирлар юк, метанол микъдары ГОСТта каралган күрсәткечләрдән 10–100 тапкыр, аракы майлары күләме 1,5–10 тапкыр кимрәк. 2000 елларда ТРның С.һ.л.-а.җ.с. пр-тиеләре ел саен «Fancy food show» (Нью-Йорк), «Monde Selection» (Бельгия), DLG (Германия), «Продэкспо» һәм «Эчемлекләр индустриясе» (Мәскәү), «Петербург шәраблар һәм аракылар ярминкәсе» һ.б. абруйлы халыкара һәм бөтенроссия күргәзмә-конкурсларының 600 гә якын призына һәм бүләгенә лаек була. Иң яхшы брендларга Алкогольле эчемлекләр сыйфаты өчен милли бүләк, «Россиянең иң яхшы 100 товары» билгесе бирелә. Дәрәҗәле бүләкләргә «Экстра», «Люкс», «Альфа» категорияле спиртлар, «Premium» класслы аракылар («AKDOV Ultimate», «Ханская», «Русская валюта»), «Старая Казань», «1000-летие Казани» аракылары, «Ваш выбор» аракы линияләре һ.б. лаек табыла.

Эшләп чыгарылган спиртның 90% тан күбрәк өлеше алкоголь продукциясе җитештерү-



С.П. Спирьков.

дә файдаланыла. Спирт ш.у. парфюмерия-косметика, фарм., мед., микробиол., радиоэлектроника һ.б. тармак пр-тиеләре тарафыннан кулланыла.

«Татспиртпром» АҖ респ-каның социаль-икътисади тормышында актив катнаша (финанс ярдәме күрсәтә). Аның карамагында Халыкара «Казан» ат спорты комплексы һ.б. спорт корылмалары бар. «Татспиртпром» АҖ хисабына ятим балалар өчен 2 социаль приют, балалар йорты, инвалидлар һәм картлар интернат йорты тотыла. Тармак өчен кадрларны Казан технол. ун-ты, Казан финанс-икътисад ин-ты, Казан механика-технол. техникумы әзерли.

*Әд.:* Фабрично-заводские предприятия Российской империи. П., 1914; Д р о н о в а Т.И., Д р о н о в П.Р. Огонь, мерцающий в сосуде: 100 лет Чистопольскому ликёроводочному заводу. Наб.Челны, 2001; М и х а л е в и ч И.Б. О рынке алкогольной продукции в Республике Татарстан // Экон. вестн. РТ. 2007. № 1; Тематическая подборка, посвящённая 10-летию АО «Татспиртпром» // Рус. водка плюс. 2008. № 2/3.

*М.Ж.Гаитов, И.Б.Михалевич.*

**СПИРЬКО́В** Степан Петрович (27.12.1904, Алабуга ш. — 2.9.1982, Мәскәү), Сов. Союзы Герое (21.3.1940), полковник. Куйбышев Затоны посёлогындагы суднолар ремонтлау з-дында эшли. 1926–28 елларда һәм 1931 дән Кызыл Армия Хәрби пехота уч-щесен тәмамлый. Совет-фин сугышында катнаша, 330 нчы укчы полкның (7 нче армиясенең 86 нчы укчы дивизиясе) батальон командиры. Төньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре составында Виипури шәһәре (хәзер Ленинград өлкәсенең Выборг ш.) янындагы сугышларда батырлык күрсәтә: 1940 ның мартында С. җитәкчелегендәге батальон, дошманның тере көчләре һәм сугышчан техникасына зур зыян китереп, Скиппари торак пунктының төньяк читен яулап ала. Вилайоки пункты өчен барган бәрелештә С. авыр яралана, әмма сугыш кырын ташлап китми. Бөек Ватан сугышы елларында Казан, Ульянов, Загорск шәһәрләрендә хәрби комиссар булып эшли. 1954 тән отставкада, Мәскәүдә яши. Ике Ленин ордены, Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СПИ́ЦЫН** Александр Андреевич (26.8.1858, Вятка губ. Яранск ш. — 17.9.1931, Ленинград), тарихчы, археолог, СССР ФА мөхбир әгъзасы (1927). Россиядә археологиягә нигез салучыларның берсе. Петербург ун-тын тәмамлый (1822). 1882–92 елларда Вятка Мария хатын-кызлар гимназиясендә укыта. 1892 дән Император сарае министрлыгында (С.-Петербург), 1914 тән Петроград археол. ин-тында, 1919–29 да Матди мәдәният тарихы дәүләт академиясенең этнология бүлегендә рус археологиясе разряды мөдире. 1909–27 дә Петербург (1924 тән — Ленинград) ун-тында, проф. (1918); Археол. кабинетын оештыручы (1910). Казан ун-ты каршындагы Археол., тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы (1878), Рус археол. җәмгыяте музее хакыйкый әгъзасы, саклаучысы (1907). 1880–90 да Вятка, Казан һәм Пермь губерналарындагы тарихи истәлекләрдә археол. тикшеренүләр уздыра. Элгәреге болгар чоры истәлекләрен (ш.и. Танкеевка каберлеген) башлап өйрәнүчеләрнең берсе. Балымер каберлеге һ.б. истәлекләр материаллары буенча Көнчыгыш Европадагы борынгы венгр әйберләре комплексын билгели (1914). Бер үк вакытта тарихи истәлекләрне палеолиттан башлап урта гасырларның соңгы дәвере арасына караган тарихи истәлекләрне чорларга бүлү б-н шөгыльләнә. Классификацияләүче һәм системалаштыручы буларак, С. эшчәнлеге нәтиҗәсендә карточкалар каталогы яисә «Спицын катыргылары» дип аталган каталог барлыкка килә. Кама буе истәлекләренең күпчелегенең хронологиясен һәм чорларга бүленешен эшли, *Пьянобор культурасын* аерып күрсәтә. Беренче булып, мари һәм удмурт халыкларының хәзерге вакытта урнашкан терр-яләрендә аларның иң борынгы чорлары формалашуы турында нәтиҗә ясый. Хезмәтләре бронза һәм элгәреге тимер гасырлар археологиясен, Кама буеның урта гасырлар тарихын, славян-рус борынгылыкларын өйрәнүгә карый. «Рус тарихи географиясе» («Русская историческая география», П., 1917) уку ярдәмлеге авторы.


Х е з м.: Оброчные земли на Вятке в XVII в. // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1892. Т. 10; Археологические разыскания о древнейших обитателях Вятского края // Материалы по археологии восточных губерний России. М., 1893. Вып. 1; Древности бассейнов рек Оки и Камы // Материалы по археологии России. 1901. № 25; Древности Камы по раскопкам А.А.Спицына в 1898 г. Л., 1933.

*Әд.:* С п и ц ы н А.А. Мои научные работы // Сборник статей по археологии и византиноведению, изданный семинарием им. Н.П.Кондакова. Прага, 1928. Т. 2; Ж е б е л е в С.А. Археолог-энтузиаст (Памяти А.А.Спицына) // Советская археология. 1948. Т. 10; Ж д а н (Спицына) Е.А. Из далёкого прошлого. Калуга, 1999; История и практика археологических исследований: Материалы Междунар. науч. конф., посв. 150-летию со дня рождения чл.-корр. АН СССР, проф. А.А.Спицына. СПб., 2008.

*С.В.Кузьминых.*

**СПО́РИУС** Алексей Андреевич (19.8.1930, Казан — 15.8.1999, шунда ук), архитектор, төзүче инженер, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1977). А.Э.*Спориусның* улы. 1953 елда Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый, «Гипротатнефть» ин-тында эшли. 1955 тән ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы, 1957 дән «Татаргражданпроект» ин-ты проектларының баш архитекторы, 1988 дән «Архпроект» остаханәсе архитекторы. Бер үк вакытта, 1972–99 да, Казан архит-ра-төзелеш академиясенең архитектур проектлау кафедрасында укыта. Архитекторлар берлеге (1957) һәм Рәссамнар берлеге (1998) әгъзасы. Казанда С. проектлары буенча ТАССР ВДНХсының төп капкасы (1957, хәзер «Казан ярминкәсе»), Үзәк стадион (1960, автордашлары П.А.Саначин, Г.И.Солдатов, О.И.Берим), КПССның Татарстан өлкә ком-ты Сәяси мәгариф йорты (1966; автордашы П.А.Саначин, хәзер ТР ФА бинасы), Актёрлар йорты (1967, автордашлары В.А.Петров, Н.Г.Хәйруллин), «Совет властe өчен көрәштә һәлак булганнар истәлегенә монумент» (1967, автордашлары Г.М.Пичуев, В.Г.Нагорный), «Шәфәгать» Мәрьям Ана иконасы һәм Изге Серафим Саровский храмнары комплексы (1999–2005) төзелә.

С. эскизлары буенча Казанда А.Алиш исем. Пионерлар сарае (1960), «Волга» кунакханәсе (1966), «Теплоконтроль» з-дының адм. корпуслары (1966), Татар ашлары йорты (1970), «Казан» кунакханәсе (1970 еллар





А.А.С п о р и у с. 1. «Казан. Благовещение соборы». Кәгазь. акварель. 1980;
2. «Зөя атау-шәһәре». Кәгазь. Акварель. 1992.

ахыры), Яшел Үзәндә — Андрей чиркәве (1998), Кишинёвта хөкүмәт биналары (1979) интерьерлары бизәлә.

С.ның акварель техникасында сәнгатьчә югарылыкта башкарылган эшләре Россия һәм Халыкара күргәзмәләрдә катнаша, шәхси күргәзмәсе Казанда 1998 дә үткәрелә.

*Л.Е.Спориус.*

**СПО́РИУС** Андрей Эмильевич (3.11.1904, Казан — 18.6.1961, шунда ук), архитектор. 1929 елда Томск технол. ин-тын тәмамлый. 1930 дан — архитектор, В.И.Ленин исем. Казан дары з-дының сәнәгать р-ны башлыгы. 1933 тән «Татпроект» проектлау конторасы архитекторы, 1935–49 да һәм 1955 тән Казан киноплёнка ф-касы КБның баш архитекторы, җитештерү бүлеге башлыгы. 1950–55 тә ТАССР МС Төзелеш һәм архит-ра эшләре идарәсенең архит-ра-планлаштыру остаханәсе баш инженеры. Бер үк вакытта, 1931–41 дә, Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тында укыта; 1951 дән «Гипротатнефть» ин-тында баш инженер булып эшли. Архитекторлар берлеге әгъзасы (1934), Архитекторлар берлегенең Татарстан бүлеге рәисе (1948–58). Казанда С. проектлары буенча 85 объект: җәмәгать биналары, торак йортлар, мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре һ.б., ш.и. конструктивизм стилендә — ТАССРның 10 еллыгы исем. мәдәният йорты (1930–31; 2009 да сүтелә), Тукай урамындагы торак йорт (1930 еллар башы), «Эрмитаж» бакчасындагы Җәйге театр (1933; сүтелә) төзелә. Совет неоклассицизмы стилендә Восстание урамында Казан киноплёнка ф-касының сәнәгать һәм адм. корпуслары, эшчеләре өчен торак йортлар төзелә (1935–50). Казан җитен комб-тының җитештерү һәм адм. биналарына реконструкция үткәрелә (1935–36).

*Х.Г.Надыйрова.*

**СПОРТ КЛУБЛАРЫ́**, җәмәгать физкультура-спорт берләшмәләре төре, сәламәтлекне ныгыту, актив ял һәм яхшы физик әзерлек тәэмин итү, спорт резервын әзерләү, ш.у. югары казанышлы спортны үстерү максаты б-н җитештерү (пр-тиеләрдә, оешмаларда, белем бирү учреждениеләрендә) яисә терр. принцип буенча оештырылалар. Татарстанда физкультура һәм спорт эшләрендә югары күрсәткечләргә ирешкән *физик культура коллективлары* С.к. статусын алалар: «Рубин» (1962), М.Урицкий исем. (1963), Я.Юдин исем. (1963), В.Воровский исем. (1965), «КАМАЗ» (1975), «Электрон» (1987), «Нефтехимик» (1988), «Ракета» (1988), «Стрела» (1991). 1990 еллар башыннан ТРда төрле милек формалары һәм ведомстволар карамагында С.к. юридик рәсмиләштерелә. Алар арасында: футбол клублары — «Рубин» (Казан), «КАМАЗ» (Чаллы), «Әлнас» (Әлмәт), «Позис» (Яшел Үзән); хоккей командалары — «Ак Барс» (Казан), «Нефтяник» (Әлмәт), «Нефтехимик» (Түбән Кама), «Динамо-Казан» (чирәмдәге хоккей); баскетбол клублары — «Нур», «УНИКС» (икесе дә — Казан); ату командалары — «Снайпер» (Чаллы), «Робин Гуд» (арбалет), «Вольный стрелок» (пейнтбол, икесе дә — Казан); ат спорты клублары — «Аргамак» (Казан), «Ягуар» (Норлат ш.); спорт-сәламәтләндерү клублары — «Сокол» (Казан, Чаллы ш.), «Атлант» (Чаллы ш.), «Атлет» (Яшел Үзән ш.); бию клублары — «Бригантина», «Ритм» (икесе дә — Казан); регби клубы — «Стрела» (Казан); өстәл теннисы — «Тайфун», «Ш.А.Тарпищев исем. Теннис академиясе» (Казан); волейбол — «Зенит-Казан»; заманча һәм экстремаль спорт төре — «Экстрим Фактор» (байк, сноуборд, скейтборд, роликлар, Казан); ватерпол — «Синтез» (Казан); шахмат-шашка клубы (Чаллы); техник клуб — «Картинг-үзәк», аэроклуб «Аэротрейд», мотоклуб «Freemen» (барысы да — Казан), скутерклуб — «Skooter Brothers» (Чаллы), авиация спорт-техника клубы «Дельта-КАМ» (Түбән Кама); спортча йөзү буенча ветераннар клубы — «Идел» (Казан).

**СПОРТ КЛУБЫ́**, М.С.Урицкий исем., к. *«Ак Барс»*.

**СПОРТ МӘКТӘПЛӘРЕ́**, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре төре, 6 яшьтән 18 яшькә кадәр булган балаларны һәм яшьләрне массакүләм физик культурага җәлеп итү һәм яшь спортчылар әзерләү б-н шөгыльләнәләр. Татарстанда беренче спорт мәктәпләре 1930 елларның 2 нче яртысында профсоюзларның ирекле спорт җәмгыятьләре, «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте, ТАССР Мәгариф халык комис-ты, ТАССР ХКС каршындагы Физик культура һәм спорт эшләре буенча ком-т системасында барлыкка килә. 1954 тә аларның саны 24 (5 меңнән артык укучы), 1974 тә 50 (19 мең укучы) була, шуларның 5 се — махсус мәктәпләр. 1970 елларның 2 нче яртысында Казан район халык мәгарифе бүлегенең 3 нче Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе (директоры — И.Б.Брен) СССРда иң яхшысы булып таныла. 1990 да 39 спорт төре буенча 104 С.м. исәпләнә, анда 57472 кеше шөгыльләнә. 2016 га Татарстанда физкультура-спорт юнәлешендә 176 балаларга өстәмә белем бирү учреждениесе эшли (139 балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе һәм 25 олимпия резервындагы махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе), аларда якынча 90 мең кеше шөгыльләнә (ТР белем бирү учреждениеләрендә укучыларның гомуми санының 24%). С.м.ндә спортның 72 төре җәелдерелә, иң күп кеше шөгыльләнүче төрләре: хоккей (якынча 10 мең кеше), футбол (8 меңнән артык), волейбол (6 меңнән артык), көрәшнең милли төрләре (4 меңнән артык), чаңгы ярышлары (4 меңнән артык), спорт гимнастикасы (3 меңнән артык), бокс (3 меңнән артык), нәфис гимнастика (3 меңнән артык), дзюдо (3 меңнән артык), шахмат (3 меңнән артык).

**СПОРТ МУЗЕ́Е**, Ш.Х.Галиев исемендә, Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы карамагында, 1996 елда Казанда Физик культура, спорт һәм туризм дәүләт ком-тының Үзәк спорт клубы җирлегендә нигезләнә (Ш.Х.*Галиев* башлангычы б-н), 2001 дә *Спорт сараенда* ачыла. Үз эченә «Олимпия даны», «Спорт тарихы» залларын (һәрберсе 150 *м*²), кече зал һәм адм. биналарны (мәйданы 100 *м*²) ала. С.м. фондында 10 меңнән артык берәмлек экспонат — даими һәм 1 мең берәмлек вакытлыча саклауда. С.м.ның беренче иҗтимагый советы әгъзалары — Ш.Х.Галиев (рәис), Н.Т.*Колчин*, Н.Ф.Курынова, З.Н.Пантелеева. Директорлары — Е.Р.Вәлиуллова (2001–2002), А.М.Яруллина (2003 тән).

**СПОРТ САРАЕ́**, Казанда. Файдалануга 1966 елда тапшырыла (арх. М.Х.Агишев), «Труд» ирекле спорт җәмгыятенең Татарстан өлкә советы (1990 кадәр), Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсенең «Итиль» хоккей-спорт клубы (1990–95), ТРның Физик культура, спорт һәм туризм дәүләт ком-ты (1995–2002), ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы (2001 дән), 2005 тән ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы карамагында. 1998–2000 елларда тамырдан үзгәртеп корыла: 2 хоккей мәйданчыгы, күнегүләр, тренажёр, гимнастика спорт заллары төзелә, фойе киңәйтелә һ.б. (арх. Г.А.Бакулин, М.Г.Хәйруллин һ.б.). Корылмалары: 3845 урынлы тамашачылар залы б-н 61×30 *м*² үлчәмле боз мәйданчыгы; 1100 урынлы трибуналар б-н боз мәйданчыгы; тренажёр, күнегүләр, гимнастика, хореография спорт заллары. Казандагы С.с. — ТРда иң зур спорт корылмасы, халыкара стандартларга туры килә (матбугат үзәге, теле- һәм радиокомментаторлар бүлмәсе: радиоузел, кафе һ.б.), алкалы («Ак Барс») һәм туплы («Ракета») хоккей командаларының, алкалы хоккей («Бөркет») һәм тимераякта фигуралы шуу буенча олимпия резервындагы респ-ка махсус балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләренең уку-тренировка һәм ярышлар базасы санала. 2001 дә С.с.нда ТРның *Спорт музее* ачыла (2009 дан Ш.Х.Галиев исемендә).

**«СПРА́ВОЧНЫЙ ЛИСТО́К»** («Белешмәләр сәхифәсе»), реклама һәм игъланнар газетасы. 1886 елның гыйнварыннан 1890 ның 3 маена кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 100 саны чыга. Даими чыкмый (1886 да — 53, 1887 дә — 27, 1888 дә — 26, 1889 да — 5 сан). Нашире һәм мөхәррире — Казан ун-ты басмаханәсе башлыгы А.Т.*Соловьёв*. Газета шәхси һәм казна игъланнарын, ш.у. «шәхси тормышта гамәли әһәмияткә ия» кыска мәкаләләр бастыруны максат итеп куя. Һәр санда диярлек Казан ун-ты басмаханәсе хезмәтләре рекламасын бирә. Университет басмаханәсенең даими заказчылары 5 юлга бушлай игълан бирә алган. Газетада китап кибетләренә килгән китапларга анонска күп урын бирелә, кайвакыт җентекле рецензияләр басыла. «Белешмәләр бүлеге»ндә кунакханәләр, мунча, даруханә, басмаханәләр, поезд, пароход расписаниеләре, коммерцияле фирмалар, кибетләр рекламасы дөнья күрә. Казан табибләренең кабул итү вакытын һәм урынын күрсәткән игъланнар еш була. Коммерциясез мәгълүмат бүлегендә Төньяк телеграф агентлыгы телеграммалары, сәнәгать, а.х., сәүдә хәле һәм үсеше турында танып белү характерын-

дагы зур күләмле, ш.и. Казан төбәге буенча да мәкаләләр басыла. 1886 да газета һөнәрчелек һәм а.х. күргәзмәсенә зур игътибар бирә. «С.л.» җирбиләүчеләргә тапшыру өчен земство управаларына, волость идарәләренә, уч-щеләргә, китап б-н сәүдә итүчеләргә җибәрелә, пароход каюталарына таратыла. Казан ун-ты басмаханәсендә басылган игъланнар аерым түләү бәрабәренә газета б-н таратыла һәм шәһәр буйлапябыштырып чыгыла. Газета реклама бирүчеләр арасында зур уңышка ирешми, башка Казан басмалары: «*Казанский биржевой листок*», «*Листок объявлений*» һ.б. б-н реклама буенча көндәшлектә калыша. 1890 да аңа хокукны «Казанский биржевой листок»ның элеккеге мөхәррире Н.А.Ильяшенко сатып ала һәм исемен «*Казанские вести*» дип үзгәртә.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«СПРА́ВОЧНЫЙ ЛИСТО́К ГО́РОДА КАЗА́НИ»**, («Казан шәһәренең белешмәләр сәхифәсе») Казандагы беренче хосусый газета. Белешмә сәхифәсе Россиядә басма буларак 1860–70 елларда үсеш ала, җирле универсаль газеталарның (рәсми губ. басмаларына өстәмә буларак) дәвамчысы була. 1860 та Идел буе шәһәрләрендә «Саратов шәһәренең белешмәләр сәхифәсе» («Справочный листок г.Саратова», 1863), «Әстерхан белешмәләр сәхифәсе» («Астраханский справочный листок», 1965), «Самара белешмәләр сәхифәсе» («Самарский справочный листок», 1866–88) һ.б. басыла башлый. Шәһәр хөкүмәте ярдәме б-н мондый басма Казанда да барлыкка килә. Газета 1867 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр атнага 3 тапкыр рус телендә нәшер ителә, барысы 146 сан чыга. Нашире һәм мөхәррире — Казан ун-тының рус хокукы тарихы каф. доценты С.М.*Шпилевский*. Актив авторлары арасында — Н.Я.Агафонов, Н.Н.Булич, А.М.Бутлеров, П.П.Васильев, В.В.Владимиров, Н.А.Головкинский, Н.И.Золотницкий, А.Лебедев, В.Магнитский, В.П.Невельской, И.М.Николич, В.Н.Тиманова, С.И.Черепанов. Материалларның күп өлеше Казан тормышына багышлана. Гомумсәяси һәм хөкүмәт материаллары аз була (башлыча, Петербургның «Северная почта» г-тасыннан күчереп алынганнар). Дворян һәм Сәүдәгәрләр җыеннарындагы вакыйгалар, хәйрия акцияләре, театр һәм музыка тормышы турында хәбәр ителә. Газета театр тамашалары турындагы игъланнар, бенефисларга бәяләмәләр б-н тулган була. П.Васильевның «Казан театры тарихы өчен материаллар» («Материалы для истории казанского театра»), С.Шпилевскийның «Казан театры тарихы...» («История казанского театра...») язмалары, 1867 нең 15 октябрендә шәһәр театры, Александр бакчасында җәйге театр ачылу турындагы материаллар басыла. Шәһәрдә һәм өлкәдә мәгариф торышы яктыртыла: ун-т, гимназияләр һәм уч-щеләр тормышы һәм тарихы турында кыска мәкаләләр дөнья күрә. Игътибар үзәгендәге мәкаләләр: В.Владимировның «Киләчәк 1868 елның 21, 22 һәм 23 гыйнварында 1 нче Казан гимназиясенең 100 еллыгына багышланган тантаналы юбилеен бәйрәм итү» («Празднование торжества столетнего юбилея 1-й Казанской гимназии 21, 22 и 23 января будущего 1868 года»), Н.Фастрицкийның «18 йөзнең икенче яртысында хәзерге университет кварталы» («Нынешний университетский квартал во второй половине 18 столетия»), И.Николичның «Казандагы Мария хатын-кызлар училищесе» («Мариинское женское училище в Казани»). Газетаның озак вакытка исәпләнгән зур акцияләреннән берсе «Справочный листок...»та шәһәр халкының эчәргә яраклы су б-н тәэмин ителешен укучылар б-н уртага салып тикшерүдән гыйбарәт була. «Казанда суүткәргеч сузу ком-ты кушуы буенча әлеге ком-т әгъзалары Граве, Больцани һәм Бутлеров тарафыннан әзерләнгән Казан Шәһәр Думасына мөрәҗәгать проекты»н («Проект отношения в Казанскую Градскую Думу, представленного согласно поручению комитета по устройству в Казани водопровода, членами сего комитета Граве, Больцани и Бутлеровым») бастырудан башлана. Проект авторларыннан кала, аңарда табиб Н.А.Виноградов, геолог Н.А.Головкинский, арх. П.Т.Жуковский, сәнәгатьче Н.К.Крестовников, гигиена белгече А.И.Якобий һ.б. катнашалар. Шәһәрне төзекләндерү: урамнарны яктырту, күперләр, бульварлар, дамбаның Бишбалта бистәсенә кадәрге участогы торышы һ.б. турындагы материаллар басыла. Кабан күлендәге пароходта йөреп күңел ачып кайту эшен оештыру, Зөя авылы б-н җәйге элемтә турындагы мәсьәләләр куела. «Иделдән» сәхифәсендә навигация торышы турында җентекле мәкаләләр басыла; календарь бүлегендә православие һәм мөселман бәйрәмнәре, ш.у. халык бәйрәмнәре (чуаш, удмурт, мари) турында белешмәләр бирелә. Матбугат күзәтүләреннән Н.Я.Агафоновның «Рус газеталарындагы узган ел Казаннан юлланган язмаларга күзәтү» («Обозрение корреспонденций из Казани в русских газетах за прошедший год»), П.П.Васильевның «1866 елда Казанда яздырып алынган вакытлы басмалар статистикасы» («Статистика периодических изданий, получаемых в Казани в 1866 г.») аеруча кызыксыну уята. Акча, кадрлар җитешмәү, матбугатны тарату системасы булмау, укучыларның игътибары җитмәү сәбәпле, газета чыгудан туктый. Әмма «Справочный листок...» басмасының тәҗрибәсен уңышлы дип табалар, Шпилевский «*Казанские губернские ведомости*» г-тасының рәсми булмаган өлешенә мөхәррир итеп чакырыла, 1881 дән «*Волжско-Камское слово*» г-тасын нәшер итә башлый.


*Әд.:* П е т р о в с к и й Н.М. Первая частная газета в Казани // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1919. Т. 30, вып. 1; Казань, 1867 год (Указатель содержания газеты «Справочный листок города Казани»). К., 1992.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«СПУ́ТНИК АГИТА́ТОРА»**, журнал; к. «*Коммунист Татарии*».

**СПУ́ТНИК АША́ ЭЛЕМТӘ́**, Җирнең ясалма иярченнәренә (спутникларга) урнаштырылган ретрансляторлардан файдалануга нигезләнгән радиоэлемтә төре. Мәгълүматны (телефон, теле- һәм радиотапшырулар, компьютерлар һ.б. аша) берничә мең *км* ераклыкка кадәр тапшыру мөмкинлеге бирә. Халыкара радиоэлемтә берлеге стандартлары буенча С.а.э.нең төрле төрләре өчен 1–30 *ГГц* ешлык диапазонындагы радиодулкыннар кулланыла. С.а.э. челтәренең җирдәге антенналарына көчле радиотапшыргычлар, антенналар, комачаулау дәрәҗәсе иң түбән булган кабул итү җайланмалары урнаштырыла. Элемтә спутниклары сигналны кабул итү, эшкәртү, көчәйтү һәм ретрансляцияләүнең электрон аппаратлары б-н җиһазландырыла.

Ретрансляция спутникларының күп өлеше Җир экваторы яссылыгында ятучы түгәрәк геостационар орбитада (биеклеге 35,8 мең *км*) урнаша. Планетаның әйләнү юнәлеше буенча һәм аның әйләнү тизлеге б-н хәрәкәт итеп, алар Җир өслегенә карата хәрәкәтсез калалар һәм, поляр өлкәләрдән тыш, зур гына мәйданнарда өзлексез элемтә булдырып торалар. Геостационар орбитага урнаштырылган спутниклар саны чикләнгән. Экватордан ераграк торучы киңлекләрдә урнашкан районнар (мәс., Россиядәге) өчен югары эллиптик орбиталарда хәрәкәт итүче (апогей 40 мең *км*, перигей 460–630 *км* тирәсе) спутниклар кулланыла. Геостационар һәм эллиптик орбиталарның артык биеклеге аңа спутниклар җибәрүне кыенлаштыра, кабул ителә торган радиосигналларның көчсезлегенә һәм тоткарлануына (0,5 *с* ка кадәр) сәбәпче була, җирдәге станцияләрдә файдалы мәйданы зуррак булган антенналар, көчләрәк кабул итү-тапшыру җиһазлары куллану зарурлыгын тудыра. Уртача биеклектәге (5 меңнән 20 меңгә кадәр *км*) һәм түбән (700 дән 1500 *км* га кадәр) түгәрәк орбиталарда хәрәкәт итүче спутниклар кабул итү сигналларының югары дәрәҗәсен тәэмин итә, шуңа күрә алар б-н элемтәне кечерәк антенналы хәрәкәтчән җайланмалар урнаштыра ала; сигналның таралуы 0,13 *с* тирәсенә тоткарлана һәм элемтәнең сыйфатына тәэсир итми диярлек. Әмма спутникның очыш биеклеген киметү ул хезмәт күрсәтә торган мәйданны һәм аның җирдәге станциядән күренү вакытын



кыскарта; бу исә өзлексез элемтә тәэмин итү өчен кирәкле спутниклар санын арттыруга китерә.

1962 елда Атлантик океан аша беренче спутник телетапшыруы була. СССРда (эллиптик «Молния-1») һәм чит илләрдә (геостационар «INTELSATI») даими спутник элемтәсе 1965 тә кулланыла башлый. Россия терр-ясендә хезмәт күрсәтүче төп халыкара С.а.э. системалары: GlobalStar (тавышлы элемтә, кыска хәбәрләр хезмәте, роуминг; факсимильле элемтә, мәгълүмат тапшыру һ.б.), Inmarsat (диңгез, елга һәм авиация транспортында) һәм Thuraya (мобиль спутник һәм телефон элемтәсе һ.б. җир өсте кәрәзле челтәрләр хезмәтенә өстәмәләр).

Татарстанда беренче С.а.э. каналларын 1990 еллар башында «Белком» һәм «Татинком» фирмалары оештыра. Җир өсте системаларын гамәлгә куючы һәм С.а.э.нең федераль операторы — Чистай шәһәрендәге «Вектор» радиокомпаниясе (1986 да КБ буларак оештырыла). 2001 дә Россиядә беренче региональ космик телевидение үзәге һәм «Яңа гасыр» респ-ка телерадиокомпаниясенең спутник аша тапшырулар системасы куллануга тапшырыла, нәтиҗәдә, программаларны барлык ТР халкы, ш.у. РФ төбәкләрендәге, якын һәм ерак чит илләрдәге татар диаспорасы өчен трансляцияләргә мөмкин була. С.а.э. өлкәсенә белгечләрне Казан техник ун-тының радиоэлектрон һәм телекоммуникацион системалар кафедрасы әзерли.

*Әд.:* Спутниковая связь и вещание. М., 1997; Камнев В.Е., Черкасов В.В., Чечин Г.В. Спутниковые сети связи. М., 2004; Стахов Е.А. Спутниковые и радиорелейные системы передачи информации. К., 2008.

*Е.А.Стахов.*

**«СПУ́ТНИК ПАРТИ́ЙНОГО АКТИВИ́СТА»**, журнал; к. «*Коммунист Татарии*».

**СССР**, к. *Совет Социалистик Республикалар Союзы.*

**СССР ФА ОЕШМАЛАРЫНЫ́Ң КАЗА́Н ТӨРКЕМЕ́**. СССР ФАнең эвакуацияләнеп килгән оешмалары нигезендә 1942 елның май аенда төзелә. 1941 нең июлендә СССР ХКС каршындагы эвакуация советы карары б-н Казанга СССР ФАнең 85 фәнни оешмасының 33 е, 1884 фәнни хезмәткәр, ш.и. 93 акад. һәм мөхбир әгъза (гаиләләре б-н 5 меңгә якын кеше) эвакуацияләнә. Килүчеләр арасында академиклар А.И.Абрикосов, С.И.Вавилов, И.М.Виноградов, А.В.Винтер, Б.Г.Галёркин, И.В.Гребенщиков, Б.Д.Греков, А.М.Деборин (Иоффе), Н.С.Державин, А.Ф.Иоффе, П.Л.Капица, М.В.Кирпичёв, В.А.Кистяковский, А.Н.Колмогоров, Н.Е.Кочин, Г.М.Кржижановский, А.Н.Крылов, В.Ф.Миткевич, С.С.Намёткин, С.П.Обнорский, Л.А.Орбели, Н.И.Папалекси, А.Е.Парай-Кошиц, Л.И.Прасолов, Н.Н.Семёнов, К.И.Скрябин, С.Л.Соболев, Е.В.Тарле, А.М.Терпигорев, А.Н.Фрумкин, В.Г.Хлопин, Е.А.Чудаков, К.И.Шенфер, О.Ю.Шмидт; мөхбир әгъзалар Г.В.Акимов, Н.М.Беляев, И.С.Брук, В.И.Вейц, А.Г.Вологодин, А.О.Гельфонд, Б.Н.Делоне, А.В.Ефимов, М.А.Капелюшников, А.Ф.Капустинский, Ф.Н.Красовский, К.А.Круг, Н.Л.Мещеряков, А.Н.Несмеянов, А.И.Рабинович, С.З.Рогинский, Л.Н.Сретенский, С.Ф.Фёдоров, Я.И.Френкель, А.Я.Хинчин, А.Б.Чернышёв, З.Ф.Чуханов, профессорлар И.В.Курчатов, Л.Д.Ландау була. Эвакуацияләнгән фәнни-тикшеренү ин-тлары һәм фәнни учреждениеләр (лаб-яләр) Казан ун-тында һәм Татарстанның башка оешма һәм пр-тиеләре терр-ясендә урнаша. СССР ФА учреждениеләренең җирле фәнни оешмалар һәм сәнәгать пр-тиеләре б-н эшчәнлеген координацияләү өчен, ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты каршында *Фән-техника комиссиясе* (рәисе — О.Ю.Шмидт) оеша. 1941 нең августыннан 1942 нең маена кадәр Казанда вице-президентлар О.Ю.Шмидт һәм Е.А.Чудаков җитәкчелегендә СССР ФА Президиумы эшли. 1942 нең маенда СССР ФА Президиумы карары б-н СССР ФА Президиумының яңа составы сайлана (аның торган урыны булып Свердловск шәһәре тәгаенләнә), Казанда СССР ФА оешмаларының Казан төркеме (җитәкчеләре итеп А.Ф.Иоффе һәм Л.А.Орбели билгеләнә) оеша. Бөек Ватан сугышы б-н бәйле рәвештә туган фәнни-техник мәсьәләләрне хәл итү өчен, берничә фәнни комиссия — *СССР ФАнең хәрби диңгез флоты фән-техника мәсьәләләре комиссиясе, СССР ФАнең авиация мәсьәләләре комиссиясе, СССР ФАнең Урта Идел һәм Кама буе ресурсларын илне саклау ихтыяҗларына мобилизацияләү комиссиясе, СССР ФАнең азык-төлек ресурслары мәсьәләләре комиссиясе* төзелә. Бу вакыт эчендә СССР ФА галимнәре илнең оборона сәнәгате үсешенә зур өлеш кертә: СССР ФАнең органик химия ин-тында җитәкчесе А.Н.Несмеянов җитәкчелегендәге карбиноллар алу (яралары дәвалау өчен кулланыла) методикасы уйлап табыла; О.К.Богданов җитәкчелегендә тиоколь каучук алуның эмульсияле алымы ачыла; К.С.Топчиев җитәкчелегендәге төркем $B_1$ витамины синтезын гадиләштерә; А.Ф.Иоффе металлар физикасы өлкәсендә яңа чишелешләр бирә; Г.В.Акимов җитәкчелегендәге төркем детальләрне анодлы оксидлаштыруның яңа ысулын эшли; Н.Г.Четаев самолётның җир буенча хәрәкәтендәге тотрыклылыгын исәпләү теориясен уйлап таба; П.Л.Капица сыек кислород алу чарасын камилләштерә; С.Ф.Фёдоров җитәкчелегендәге төркем Шөгер, Сарабиккол тирәсендә, Аксубай торгынлыгы зонасы һ.б.да нефть табыла торган мәйданнарны ачыклый. 1943 тә учреждениеләрнең бер өлеше Мәскәүгә кире кайта. 1945 нең апрелендә Казанда СССР ФА ф-лы ачыла (к. *Россия Фәннәр академиясенең Казан гыйльми үзәге*).

*Әд.:* Гильманов З.И. Татарская АССР в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг. К., 1977; Ионенко И.М., Попов В.А. Казанский университет в годы Великой Отечественной войны. К., 1985; Казань и Российская академия наук: Ист.-биогр. материалы. К., 1999.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**СССР ФАне́ң АВИА́ЦИЯ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ́ КОМИ́ССИЯСЕ**. 1943 елның 15 мартында Казанда СССРның Хәрби һава көчләрен техник җиһазландыруны үстерүгә фәнни-техник ярдәм күрсәтү максатыннан оештырыла. Җитәкчесе — акад. Н.Г.Бруевич. Комиссия эшендә академиклар Н.Н.Семёнов, Н.Д.Папалекси, В.С.Кулебакин, А.Н.Колмогоров, Б.Е.Веденеев; мөхбир әгъзалар С.А.Христианович, П.Ф.Папкович катнаша. Бомбаларны төгәл ату ысуллары өйрәнелә, штурманнар өчен таблицалар төзелә, конструкцияләрнең камиллеген һәм ныклыгын яхшырту юллары тикшерелә. Комиссия эшчәнлеге Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соң туктатыла.

*Әд.:* Великая Отечественная война 1941–45: Энцикл. М., 1985.

**СССР ФАне́ң АЗЫ́К-ТӨЛЕ́К РЕСУ́РСЛАРЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ́ КОМИ́ССИЯСЕ**. 1942 елның апрелендә Казанда өстәмә азык-төлек ресурсларын табу максатыннан оештырыла. Җитәкчесе — акад. Л.А.Орбели. Ботаника (мөхбир әгъза Б.К.Шишкин) һәм зоол. (проф. Н.А.Ливанов) буенча тармак комиссияләре эшли. Комиссия эшендә СССР ФА ин-тлары (беренче чиратта Ботаника ин-ты), Идел буе югары уку йортлары галимнәре, Казандагы Табигыять фәннәре белеме җәмгыяте фәнни хезмәткәрләре катнаша. Комиссия Татарстанда балык үрчетүне киңәйтүнең яңа мөмкинлекләрен таба, сәнәгатьтә кулланыла торган кытлык майлар һәм терлек аксымнарын үсемлек маена алыштыру мөмкинлеген ача, терлекчелекнең азык базасын киңәйтүдә колхоз һәм совхозларга ярдәм күрсәтә. Комиссиянең эшчәнлеге Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соң туктатыла.

*Әд.:* Гильманов З.И. Татарская АССР в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг. К., 1977.

**СССР ФАне́ң УРТА́ ИДЕ́Л ҺӘМ КА́МА БУЕ́ РЕСУ́РСЛАРЫН ИЛНЕ́ САКЛА́У ИХТЫЯҖЛАРЫНА́ МОБИЛИЗА́ЦИЯЛӘҮ КОМИ́ССИЯСЕ**. 1942 елның июнендә Казанда Урта Идел буеның табигый ресурсларын нәтиҗәле куллану мәсьәләләрен чишүдә галимнәр тырышлыгын берләштерү максатыннан оештырыла. Җитәкчесе — акад. Е.А.Чудаков. Комиссия 8 секциядән тора: нефть (акад. С.С.Намёткин), энергетика (акад. Г.М.Кржижановский), җир асты минераль байлыклары (проф. Л.М.Миропольский), су ресурслары (акад. Ф.П.Саваренский), авыл хуҗалыгы (проф. И.С.Лупинович), зооветеринария (акад. К.И.Скрябин), химия (акад. В.Г.Хлопин), икътисад (акад. И.А.Трахтенберг). Комиссия эшендә 300 дән артык акад. һәм җирле фәнни учреждение хезмәткәрләре катнаша. Комиссия эшчәнлеге нәтиҗәсендә ТАССРда бай нефть, химик минераль чимал һәм төзелеш материаллары ятмалары, энергетика ресурслары ачыклана, аларны чыгару һәм куллану башлана. Комиссия эшчәнлеге Бөек Ватан сугышы тәмамлангач туктатыла.

*Әд.:* Гильманов З.И. Татарская АССР в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг. К., 1977.

**СССР ФАне́ң ХӘРБИ́ ДИҢГЕ́З ФЛОТЫ́ ФӘН-ТЕ́ХНИКА МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ́ КОМИ́ССИЯСЕ**. 1942 елның 3 апрелендә Казанда СССР хәрби диңгез флотын техник җиһазландыруны яхшырту максатыннан оештырыла. Җитәкчесе — акад. А.Ф.Иоффе, сек-

ретаре — проф. И.В.Курчатов. Комиссия эшендә академиклар А.Н.Крылов, В.Л.Поздюнин, проф. А.П.Александров катнаша. Яңа төр хәрби кораблар төзү һәм аларны миналардан саклау чараларын күрү буенча фәнни эшләр башкара. Бөек Ватан сугышыннан соң комиссиянең эшчәнлеге туктатыла.

*Әд.:* Великая Отечественная война 1941–1945: Энцикл. М., 1985.

**СССР ФАне́ң ХӘРБИ́ ИНЖЕНЕРЛЫ́К КОМИ́ССИЯСЕ**. 1943 елның мартында Казанда Кызыл Армиягә хәрби инженерлык мәсьәләләрендә фәнни-техник ярдәм күрсәтү максатыннан оештырыла. Җитәкчесе — акад. А.Ф.Иоффе. Комиссия эшендә Кызыл Армия баш хәрби-инженерлык идарәсенең 4 вәкиле — академиклар Б.Г.Галёркин, Е.А.Чудаков, П.И.Степанов һәм Н.Н.Семёнов катнаша. Сугыш тәмамланганнан соң, комиссиянең эшчәнлеге туктатыла.

**СССР ФАне́ң ХӘРБИ́ САНИТАРИ́Я КОМИ́ССИЯСЕ**. 1942 елның июнендә Казанда сугыш шартларында хирургия, терапия, эпидемиология, санитария-гигиена өлкәләрендә ачыш-табышларга ирешүне ачыклау максатыннан оештырыла. Җитәкчесе — акад. Л.А.Орбели. Комиссия эшендә академиклар А.И.Абрикосов, Н.Н.Бурденко, К.И.Скрябин, А.Д.Сперанский һ.б. (барысы 70 тән артык галим) катнаша. Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соң, комиссиянең эшчәнлеге туктатыла.

**СССР ФӘННӘ́Р АКАДЕ́МИЯСЕ ФӘННИ́ СЕ́ССИЯСЕ**. 1946 елның 25–26 апрелендә Мәскәүдә уздырыла. ВКП(б) ҮК һәм ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты (1 нче секретаре З.И.*Моратов*) карары б-н *Казан татарларының* килеп чыгышы турындагы мәсьәләне карау өчен чакырыла. СССР ФАнең Тарих һәм философия бүлеге һәм СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты (ТӘТИ) галимнәре конференциясе формасында уза. СССР ФАннән төп катнашучылар: акад., СССР ФАнең Тарих һәм Матди мәдәният тарихы ин-ты директоры Б.Д.*Греков*; тюрколог, СССР ФА Тел белеме ин-ты секторы мөдире, СССР ФАнең мөхбир әгъзасы Н.К.Дмитриев; тарихчы М.Н.Тихомиров; археолог һәм этнограф, СССР ФАнең мөхбир әгъзасы С.П.Толстов; археолог А.П.Смирнов; антрополог, СССР ФАнең Археол. ин-ты өлкән фәнни хезмәткәре Т.А.*Трофимова*; шәркыятьче галим, СССР ФАнең мөхбир әгъзасы А.Ю.Якубовский; Тел, әдәбият һәм тарих ин-тыннан директор урынбасары Н.И.*Воробьёв*, тарих секторы мөдире Х.Г.*Гыймади*, тел белгече Л.Җ.*Җәләй*, археолог Н.Ф.*Калинин* һ.б.

Конференциянең максаты ВКП(б) ҮКның *«Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»*гы 1944 ел 9 август карарын гамәлгә ашыру чараларын эшләү, ягъни Татарстан тарихын яктыртуда «аерым тарихчылар һәм әдәбиятчылар тарафыннан җибәрелгән милли характердагы хаталарны һәм җитди җитешсезлекләрне (Алтын Урданы артык бизәү, Идегәй турындагы хан-феодал эпосын популярлаштыру)» бетерү була.

Сессиядә акад. Б.Д.Греков рәислек итә, докладлар б-н Мәскәү, Ленинград, Казан һ.б. шәһәрләрнең күренекле тарихчылары, лингвистлары, этнографлары, археологлары, антропологлары чыгышлар ясый. Төп докладларны А.П.Смирновның «Идел буе Казан татарларының килеп чыгышы мәсьәләләренә карата» («К вопросу о происхождении казанских татар Поволжья»), Т.А.Трофимованың «Казан татарлары этногенезы антропология мәгълүматлары яктылыгында» («Этногенез казанских татар в свете данных антропологии»), Н.И.Воробьёвның «Этнография мәгълүматларына нигезләнеп, татарларның килеп чыгышы» («Происхождение татар по данным этнографии»), Л.Җ.Җәләйнең «Телгә нисбәтле мәгълүматлар буенча Идел буе татарларының килеп чыгышы турында» («Происхождение татар Поволжья по данным языка») докладлары тәшкил итә. Н.Ф.Калинин «Казан татарларының килеп чыгышына карата» («К вопросу о происхождении казанских татар»), Х.Г.Гыймади «Монгол изүе һәм Казан татарларының килеп чыгышы мәсьәләләре» («Монгольское иго и вопрос о происхождении казанских татар») исемле өстәмә докладлар б-н чыгыш ясыйлар, ш.у. М.Н.Тихомиров, С.П.Толстов, Н.К.Дмитриев, А.Ю.Якубовский, С.Е.*Малов*, В.В.Богданов, Р.М.Рәимов, Ш.И.Типеев, Ә.Б.Булатов чыгышлары тыңлана. Докладчылар һәм чыгыш ясаучыларның күбесе фикер алышканда Казан татарларының монголлардан килеп чыгуы турындагы концепциянe дә (Н.И.Воробьёв, Н.И.Веселовский), татарларны болгар кабиләләреннән «китереп чыгаручылар» (С.П.Толстов һ.б.) теориясен дә кире кага. Н.Ф.Калинин докладында «Элек үк булган, Идел буена «әзер килеш» иммиграцияләнгән һәм җирле кабиләләр, ш.у. монда башта ук яшәгән «финнар» б-н бары өлешчә генә ассимиляцияләшкән татарлар яки болгарлар турындагы күзаллар»ның яраксызлыгы билгеләп үтелә; Казан татарлары формалашу процессында мөһим рольне Идел буена Көнчыгыштан — Себердән, Енисей тирәсеннән килгән төрки телле кабиләләр уйнавы исбатлана. Х.Г.Гыймади археол., этнография, лингвистика, антропологиягә кагылышлы күпсанлы мәгълүматларның «Казан татарлары килмешәк («монгол-татарлар») түгел, ә хәзерге яшәү урынында җирле аборигеннар, төрки телле болгарлар һәм башка кардәш этник төркемнәрдән формалашкан халык» дигән гомуми нәтиҗә ясарга мөмкинчелек бирүе турындагы тезисны дәлилли. М.Н.Тихомиров чыгышында үтә конструктив фикерләр яңгырый. Ул А.П.Смирновның татар халкы формалашуда Алтын Урданың бернинди дә диярлек роль уйнамаганлыгы турындагы фикеренә шик белдерә, «Азия һәм Европаны дөньяны хасил итүчеләр сыйфатында кабул иткәндә, Алтын Урда — дөньяви әһәмияткә ия күренеш», дип билгеләп үтә. «Алтын Урдага кергән халыклар тарихыннан зур бер этапны ничек алып ташлыйсың?» дигән сорау куя. Галим Казан татарлары этногенезы турындагы мәсьәләнең тагын бер ягына — аларның хәзерге чуаш, мари, удмурт, мордваларның ата-бабалары б-н тарихтагы үзара элемтәсенә һәм бер-берсенә йогынтысына игътибар итә: «... теләсә кайсы халыкның тарихы шул терр-ядә яшәгән һәм алар б-н бәйле булган халыклар тарихы б-н бәйләнештә каралырга тиеш», — дип ассызыклый.

Сессиянең гомуми нәтиҗәсе: Казан татарлары, башка халыклар кебек үк, озак вакыт дәвамында күптөрле халыклар һәм этник төркемнәр, иң беренче чиратта *болгарлар*, аннары *кыпчаклар* б-н үзара бәйләнештә һәм аралашу барышында формалаша. Казан татарларының халык булып оешуы, башлыча, 15 йөздән соң тәмамлана. Татар тарихчылары докладчылар формалаштырган нәтиҗәләрдә һәм нигезләмәләрдә татар халкының үткәнен дәлилсез каралтудан, ягъни аның һәр вәкилен — ватан тарихын өйрәнә генә башлаган мәктәп укучыларыннан алып, югары уку йорты студентларына һәм халык хуҗалыгының төрле тармак белгечләренә кадәр — рухи яктан изү чарасыннан чыгу юлын күрәләр. Гомумән алганда, фәнни сессия рәсми Россия историографиясендә татар халкы тарихы мәсьәләләрен җитди тикшерүгә багышлаган беренче зур чара була. Анда яңгыраган фикерләр алга таба аның этногенезы һәм социаль-мәдәни тарихы концепциясен рәсмиләштерүдә мөһим фәнни-методологик роль уйный. Сессия нәтиҗәләре буенча СССР ФАнең Тарих ин-ты каршында 1946 да СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тына «Татарстан тарихы»н язуда ярдәм итү комиссиясе оеша (тарих фән. д-ры А.П.Кучкин рәислегендә). Ул татар халкы һәм Татарстан тарихы буенча язылганнарның эчтәлеген даими контрольдә тотуны гамәлгә ашыра (к. *СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтына «Татарстан тарихы»н язуда ярдәм итү комиссиясе»,* Татар энциклопедиясенең 6 нчы томында «Алдагы томнарга өстәмә» бүлегендә).

Чыг.: Происхождение казанских татар. К., 1948.

*Әд.:* Материалы по истории Татарии. К., 1948. Вып. 1. Гимади Х.Г. Об изучении истории Татарской АССР за 40 лет // Изв. КФАН СССР. Сер. гуманитар. наук. 1957. № 2; Мухарямов М.К., Гильманов З.И. Развитие исторической науки в ИЯЛИ КФАН СССР (1946–1975 гг.) // Татария в прошлом и настоящем. К., 1975; Измайлов И.Л. Не дано марксистской оценки Золотой Орде // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1996. № 3/4.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**СССР ФӘННӘ́Р АКАДЕ́МИЯСЕ**, к. *СССР Фәннәр академиясе оешмалары Казанда.*

**СССР ХАЛЫКЛАРЫ́ ҮЗӘ́К НӘШРИЯТЫ́**. Мәскәүдә, СССР ҮБКның 1924 елның 13 июнь карары нигезендә Милләтләр эшләре буенча халык комисс-тының Үзәк шәрекъ һәм көнбатыш нәшриятларын кушу юлы б-н милли телләрдә китап бастыруны үстерүгә һәрьяклап ярдәм күрсәтү максатыннан оеша. 1930 дан СССР ҮБК Милләтләр советы Президиумы карамагында. С.х.ү.н.н оештыру вакытында аңа Үзәк шәрекъ нәшриятының «Красный Восток» басмаханәсе бирелә.

1929 га басмаханәдә 60 тан артык телдә китап бастыру өчен шрифтлар була. Әлек алфавиты булмаган халыклар өчен шрифтлар булдыруда татар басмасы осталары М.И.Идрисов, Ф.Ш.Таһиров катнаша. Нәшриятта китаплардан тыш 12 телдә газета һәм журналлар, ш.и. 5 бөтенсоюз татар газетасы һәм журналы: «Игенче», «Эшче», «Фән һәм дин», «Яшь эшче», «Кечкенә иптәшләр» басыла. СССР халыклары үзәк нәшриятының редакция бүлеге каршында татар секциясе дә була (Үзәк шәрекъ нәшриятының шул ук исемдәге секциясенең дәвамчысы), басмаларның саны буенча ул немец һәм поляк секцияләреннән генә калыша. Нәшрият тарафыннан гомуми тиражы 43866 мең данә булган 7738 китап чыгарыла, аларның 781е — татар телендә.

1924 тә С.х.ү.н. мөдире итеп Н.Т.Түрәколов билгеләнә, 1930 еллар башында аны У.Ишан-Хужаев алыштыра. 1928 дә нәшрият басмаханәсендә 505 кеше эшли, алга таба аларның саны 800 гә җитә; алар арасында 10 милләт вәкиле була. Ул ВКП(б) ҮКның «Нәшрият эше турында»гы 1931 ел 15 август карары нигезендә ябыла һәм үз вазифаларын җирле нәшриятларга тапшыра.

**СТАДИОННА́Р** (грек. stádion), комплекслы спорт корылмалары. Үз эченә спорт үзәген (футбол кыры, йөгерү юллары, сикерү һәм ыргыту (чөю) өчен урыннар), тамашачылар өчен трибуналар б-н әйләндереп алынган урыннарны, тренировкалар һәм ярышлар өчен махсус җиһазландырылган (ш.и. ябык) мәйданчыкларны ала. Казанда беренче С. исәбенә (Идел буенда иң зурлары) «Татнаркомздрав» (1923 елда 2 нче Идел буе Олимпиадасын уздыру өчен ремонтлана) һәм 5 мең урынлы трибуналары б-н «Динамо» (1927 дә ачыла, 1934 тә 1 нче Идел буе Спартакиадасын уздыру өчен яңартып төзелә) С.ы керә. 1933 тә Татарстанда — 9, 1973 тә — 21, 1981 дә — 26, 1990 да 30 С. санала, алар 1500 һәм аннан күбрәк урынлы. 2014 елга 44 С. санала. Шулар исәбендә 1500 һәм аннан да күбрәк урынлы 37 С. (шуларның 9ы ясалма боз б-н) бар, Казанда — 11, Чаллы, Түбән Кама, Алабугада — 3 әр, Азнакай, Яшел Үзәндә — 2 шәр, Әлмәт, Баулы, Буа, Зәй, Лениногорск, Арча, Мамадыш, Минзәлә, Питрәч һәм Чирмешән р-ннарында 1 әр стадион. Казанда иң зур С. — «Казан Арена» (45 мең урынлы), *Үзәк стадион* (27,7 мең урынлы), «Ракета» (7,5 мең урынлы), «Рубин» (10 мең урынлы), «Хезмәт резервлары» (6 мең урынлы), «Локомотив» (5 мең урынлы), «Тасма» (3 мең урынлы), Чаллыда — «КАМАЗ» (10 мең урынлы), «Строитель» (9 мең урынлы), Түбән Камада — «Нефтехимик» (5 мең урынлы), Алабугада — «Үзәк» (5 мең урынлы), Әлмәттә — «Әлнас» (7 мең урынлы).

**«СТА́ЛИН БАЙРАГЫ́»**, фронт газетасы. Көньяк фронт, 1943 елның 20 октябреннән 4 нче Украина фронтының сәяси идарәсе органы. 1943 нең мартыннан 1944 кә кадәр татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире — Г.Клеблеев. Газета б-н И.Гази, Ә.Фәйзи, К.Хисмәтуллин, Ф.Хөсни, кызылармияче Г.Зәкиев, өлкән лейтенант Г.Якимов хезмәттәшлек итә.

**СТА́ЛИН** (Джугашвили) Василий Иосифович (21.3.1921, Мәскәү — 19.3.1962, Казан), авиация генерал-лейтенанты (1949). Качы авиация мәктәбен тәмамлый (Кырым, 1939). 1940 елдан хәрби хезмәттә. Бөек Ватан сугышында катнаша, авиация полкы, махсус авиация төркеме, авиация дивизиясе командиры. 1946–47 дә Германиядә Совет гаскәрләре төркемендә. 1947–48 дә Мәскәү Хәрби округының хәрби-һава көчләре командующие ярдәмчесе, 1948–52 дә командующие. 1953 нең апрелендә хезмәт урыныннан законсыз файдалануда һәм советларга каршы агитациядә гаепләнеп кулга алына, 1955–61 дә Владимир шәһәрендә төрмәдә утыра. Иреккә чыккач, башка шәһәргә китү хокукыннан мәхрүм ителеп, Казанга җибәрелә (апрель, 1961). Вафатыннан соң Арча кыры зиратында җирләнә. 2002 дә С.ның җәсәде Мәскәүнең Троекуров зиратына күчерелә. Өч Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә Суворов, Александр Невский орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**«СТА́ЛИН СУГЫШЧЫСЫ́»**, фронт газетасы. 1 нче Ерак Көнчыгыш фронты органы. 1945 елда татар телендә нәшер ителә, барысы 80 саны чыга. Мөхәррире — Габделхәй Хәбиб. Япониягә каршы хәрби операцияләр вакытында Ерак Көнчыгышта Кызыл Армиянең сугыш хәрәкәтләрен яктырта. Хәрби хәбәрчеләр — Г.Әпсәләмов, Г.Габид, К.Иманкулов, газетада сугышчылар Г.Җәлилов, М.Ибраһимов, З.Сафиуллин, Х.Шәмсиев еш чыгыш ясыйлар.

**«СТА́ЛИН ЭСТАФЕ́ТАСЫ»**, иҗтимагый-сәяси газета. РСФСР һәм ТАССРда наданлыкны бетерү җәмгыяте органы. 1930–32 елларда Казанда татар телендә нәшер ителә.

**СТАН**, Россиядәге адм.-терр. берәмлек, 15 йөз ахырыннан — өязнең бер өлеше. Урта Идел буе өязләрендә 17 йөз башына ныклап урнаша. 19 йөз — 20 йөз башында становой пристав җитәкләгән, берничә волостьны үз эченә алган өязнең адм. полиция берәмлеге.

**СТАНИСЛА́ВСКИЙ** Антон-Роберт Григорьевич (13.6.1817, Киев губ., Тараща өязе Ставищи а. — 9.8.1883, шул ук губернаның Белая Церковь а.), хокук белгече, тәрҗемәче, юридик фән. д-ры (1851), яшерен советник (1876). Дворяннар катлавыннан. 1834–39 елларда Киев ун-ты студенты. 1839 да, сәяси түгәрәкләрдә катнашканы өчен, Казанга сөрелә. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1840), шунда ук эшли (1843 тән, бүленеп): адъюнкт (1844–51), законнар белеме һәм дәүләт законнары энциклопедиясе каф. экстраординар профессоры (1851–53), хокук фәлсәфәсе тарихы һәм энциклопедиясе каф. ординар профессоры (1869–79). 1853–68 дә Харьков ун-тында: экстраординар проф. (1857 гә кадәр), ординар проф. (1857–68), законнар белеме һәм дәүләт законнары энциклопедиясе каф. атказ. профессоры (1868); бер үк вакытта, 1858 дән, юридик ф-т деканы, 1866 дан ректор. С. хокук тарихы мәктәбе тарафдары була. «Милеккә хокукларны ныгыту актлары хакында» («Об актах укрепления прав на имущества», 1842) хезмәтендә аерым шәхесләрнең милеккә ия булу хокуклары турындагы мәсьәләне өйрәнә. «Иң борынгы рус законнары ядкәрләрендәге милек мөнәсәбәтләре башлангычларын тикшерү» («Исследование начал имущественных отношений в древнейших памятниках русского законодательства», 1855) монографиясендә Киев Русенең гражданлык хокукы ин-тлары тарихын анализлый. «Хокук» сүзенең ике мәгънәсе: закон һәм шәхеснең сәләтлелеге» («Двоякое значение слова «право»: закон и способность лица», СПб., 1852), «Россиядә законнар белеме фәненең үсеше һәм аның хәзерге юнәлешенең нәтиҗәләре» («О ходе законоведения в России и о результатах современного его направления», 1853), «Уңай хокукның барлыкка килүе хакында» («О происхождении положительного права», Хар., 1856) һ.б. хезмәтләре хокук теориясе һәм тарихының төрле мәсьәләләренә багышлана. Дантеның «Илаһи комедия»сен («Божественная комедия», Познань, 1870) поляк теленә тәрҗемә итә. Казан ун-тының шәрәфле әгъзасы (1874).

Х е з м.: О влиянии христианства на развитие семейного права, преимущественно у римлян. Хар., 1860.

*Әд.:* А.Г.Станиславский: Некролог // Изв. Имп. Казан ун-та. 1883. № 5/8; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**СТАНКЕ́ВИЧ** Евгений Фомич (7.11.1913, Пермь губ. Оса ш. — 10.10.1992, Казан), гидрогеолог, геол.-минерал. фән. канд. (1962), Нью-Йорк ФА академигы (1995, үлгәннән соң). Казан ун-тын тәмамлый (1937). ТАССР һәм Воркута шәһәренең җитештерү оешмаларында эшли. 1956–90 елларда СССР ФА Казан ф-лының Геол. ин-тында. Хезмәтләре гидрогеологиягә, инженерлык геологиясенә, файдалы казылмаларга карый. Галогенез теориясен үстерә, СССР терр-ясендә содалы суларның киң таралуын исбатлый, бу содалы давсонит минералының беренче чыганакларын билгеләргә ярдәм итә. Татарстан шәһәрләрен су б-н тәэмин итүдә яңа чыганаклар ачыклый, шифалы минераль суларны эзләү буенча тәкъдимнәр кертә. СССР Геогр. җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы. Медальләр б-н бүләкләнә. 1945 тә репрессияләнә; 1956 да аклана.

Х е з м.: Подземные воды Татарии. К., 1967 (автордаш); Месторождения природной соды и условия их образования. М., 1973.

*Әд.:* Репрессированные геологи. М., 1980; Памяти Е.Ф.Станкевича // Литология и полезные ископаемые. 1995. № 2.

**СТАРКО́В** Рафик Фёдорович (16.7.1955, Иркутск ш.), икътисадчы, икътисад. фән. д-ры (1985), проф. (1985). Иркутск халык хуҗалыгы ин-тын тәмамлаганнан соң (1976), шунда ук стат. кафедрасында эшли. 1986 елдан Иркутск икътисад академиясенең стат. каф. мөдире. 1992 дән милли хисапчылык ассоциациясе (Франция) әгъзасы. Фәнни тикшеренүләре халыкның тормыш дәрәҗәсен үлчәү-билгеләүгә караган икътисади-статистик мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Минимальный потребительский бюджет — методология построения и анализ. Иркутск, 1992; Экономические индексы. Иркутск, 1993; Уровень жизни: методология, измерение и анализ. Иркутск, 1994.

**СТАРОВЕ́РОВ** Александр Александрович (17.11.1940, Питрәч р-ны Черемыш а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1995), проф. (2004). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2013). 1965 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Пермь полимер материаллар фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1975 тән Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан), бүлек башлыгы (1995 тән). Хезмәтләре махсус химиягә карый. С. ату коралы дарыларының сферик һәм пироксилин технологиясендә гидродинамик һәм җылылык-масса алмашу процессларын тикшерә; дарыларның физик-химик һәм баллистик характеристикалары тотрыклылыгын күтәрергә мөмкинлек бирә торган технол. режимнар эшли. Киселмә һәм шома күпшәле корал өчен бер нигезле сферик дары, ш.у. төзү-монтаж патроннары һәм газлы корал дарылары табу технологияләрен тәкъдим итә һәм җитештерүгә кертә. 100 фәнни мәкалә авторы. Уйлап табуга 180 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РФ Дәүләт бүләге (1996), РФ хөкүмәте бүләкләре (2002, 2008), ТР Дәүләт бүләге (2013) лауреаты. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Лучшие люди России: Энцикл. М., 2004. Т. 2.

**СТАРОВЕ́РОВ** Виталий Александрович (8.12.1969, Пермь ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (2005). Казан химия-технол. ин-тын (1993), Казан финанс-икътисад ин-тын (2002), «ТИСБИ» идарә ун-тын (2002) тәмамлый. 1993–2007 елларда Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында (2001 дән сектор башлыгы). 2007 дән Социаль мәгариф академиясенең Казан соц.-юридик ин-тында математика һәм информатика каф. мөдире. Хезмәтләре махсус химиягә карый. С.ның тикшеренүләре сферик дары технологияләрен камилләштерүгә, рецептур характеристикаларны һәм дары җитештерүнең чимал базасын киңәйтүгә юнәлтелгән. Фәнни эшкәртмәләре җитештерү хезмәтен, продукциянең үзкыйммәтен киметү; сферик дарыларның термодинамик һәм баллистик характеристикаларын яхшырту мөмкинлеге бирә. Хәзерге заман ату коралларының яңа буынына зарядлар эшләгәне өчен, РФ хөкүмәте бүләгенә лаек була (2002). 76 мәкалә авторы. Уйлап табуга 12 патенты бар.

**СТАРОВЕ́РОВ** Яков Петрович (21.3.1904, Казан губ., Тәтеш өязе Чинчурино а. — 17.8.1955, шунда ук җирләнә), Сов. Союзы Герое (17.10.1943), өлкән лейтенант. Әстерхан төзелеш техникумының 3 курсын, кече лейтенантлар курсларын тәмамлый (1942). Балта остасы булып эшли (Әстерхан ш.). 1926–28 елларда һәм 1941 елның июненнән Кызыл Армия сафларында. 1941 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 3 нче гв. җиңел артиллерия бригадасының 200 нче гв. җиңел артиллерия полкында идарә взводы командиры (2 нче Украина фронтының 60 нчы армиясендә 1 нче гв. артиллерия дивизиясе). Воронеж, Үзәк һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Воронеж шәһәреннән төньяктарак Дон елгасының сулъяк ярындагы оборона сугышларында (1942), Украинаның Сулъяк ярын азат иткәндә (1943), Сандомир-Силезия һөҗүм операцияләрендә катнаша (1945). Шәһәр тибындагы Дымер (Украина ССР, Киев өлкәсенең Киев-Святошино р-ны) посёлогы янында Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: 1943 нең 1 октябрендә беренчеләрдән булып елганы кичә, үзенең батареясы б-н элемтә урнаштыра һәм дошманның яр буе ныгытмаларын утка тотканда төзәтмәләр кертә. 1 октябрьдән 10 октябрьгә кадәр аның мәгълүматлары буенча дошман танклары һәм пехота төркемнәре, дүрт миномёт батареясы, 9 пулемёт ноктасы, дүрт күзәтү пункты юк ителә. Сугыштан соң — запаста, Әстерхан шәһәрендә яши. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Әстерхандагы бер урам Герой исеме б-н атала.



Я.П. Староверов.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СТАРОСЕ́ЛЬЦЕВА** Наталья Георгиевна (24.9.1971, Казан), невропатолог, мед. фән. д-ры (2007). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1994), Казан мед. академиясендә эшли, неврология, рефлексотерапия һәм остеопатия каф. профессоры (2012 дән). Хезмәтләре хроник баш мие ишемиясен өйрәнү, рефлекс комплексларын нейрофизиол. тикшерүгә карый.

Х е з м.: Спастическая кривошея. К., 2010; Генераторные системы в невропатологии. К., 2013 (автордаш).

**СТА́РОСТИН** Пётр Николаевич (24.7.1936, Мари АССРның Мари-Төрек р-ны Пинженерь а. — 3.7.2012, Казан), археолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994), тарих фән. канд. (1967). Мари пед. ин-тын тәмамлый (1960). 1963 елдан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1997 дән Тарих ин-тында (бүленеп: 1988–90 да Казан пед. ин-ты проректоры), бер үк вакытта, 1990–2004 тә, ТР ФА Тарих ин-тының Археол. тикшеренүләр милли үзәге мөдире. Мари Респ-касы, Чуаш Респ-касы, ТР, Киров, Горький (Түбән Новгород) өлкәләре һ.б. төбәкләр терр-ясендә археол. разведка һәм казу эшләре алып бара. *Имәнкискә культурасы* истәлекләрен өйрәнүгә зур өлеш кертә. Хезмәтләре элгәреге урта гасырлар чоры Түбән Кама буе тарихын һәм археологиясен өйрәнүгә карый. Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасының археологик картасы»н эшләүдә һәм төзүдә катнашканы өчен бирелә.

Х е з м.: Памятники именьковской культуры // Свод археол. памятников. 1967. Вып. Д 1–32 (автордаш); Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987 (автордаш); Нармонский могильник. К., 2002.

**СТАРШО́В** Иван Михайлович (9.4.1916, Казан губ., Чистай өязе Городище а. — 12.9.2004, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1983), проф. (1989). 1941 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казандагы оборона пр-тиесендә эшли (1941–47). 1947–51 дә фотожелатин з-дының фәнни-тикшеренү лаб-ясе башлыгы, 1951–91 дә Казан химия-технол. ин-тының нефть һәм газ эшкәртүнең химик технологиясе кафедрасында. Хезмәтләре углеводородларны түбән олефиннарга кадәр пиролизлауга; битумлы токымнарны чыгару, эшкәртү һәм куллану мәсьәләләренә; нефть чыгару процессларын интенсивлаштыруга; юл төзү материаллары эшләүгә карый. Уйлап табуга 23 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Изготовление асфальтобетона на основе битуминозных пород // Материалы Всесоюз. совещ. «Нефтебитуминозные породы: перспективы использования». А.-А., 1982 (автордаш); Использование битуминозных пород в производстве асфальтобетонных смесей // Тр. Всесоюз. конф. «Комплексное освоение природных битумов и высоковязких нефтей». К., 1991 (автордаш).

**СТАФИЛИНИДЛӘ́Р**, кыскаканатлылар (Staphylinidae), төрлечә тукланучы бөҗәкләр асотрядыннан коңгызлар семьялыгы. Гәүдәләренең озынлыгы 2–35 *мм.* Канат өслекләренең кыска булуы (икенче исеме шуннан) б-н аерылып торалар, алар корсакның бер өлешен генә каплыйлар, шунлыктан тыныч халәттә канатлары берничә тапкыр бөкләнгән рәвеш ала. Корсагы хәрәкәтчел, аска һәм өскә бөгелергә сәләтле. Дөнья фаунасында 43 меңнән артык төр исәпләнә, барлык климатик зоналарда диярлек таралганнар. Россиядә 2 меңгә якын, Татарстан терр-ясендә 259 төре билгеле. Туфракта, түшәлмәдә, чери торган үсемлек калдыкларында, гөмбәләрдә, экскрементларда, үләксәләрдә, черүче агачларда, үсемлек чәчәге һәм яфрагында, җәмгыяви бөҗәкләр ояларында, умырткалы хайваннарның өннәре һәм ояларында яшиләр. Күбесе ерткычлар, төрле вак умырткасызлар, ш.и. авыл һәм урман корткычлары, ш.у. төрле йогышлы авыруларны күчерүче паразитлар б-н тукланалар. Кайберләре агулы. Әйләнә-тирә мохит үзгәрешләренә сизгер булганлыктан, С.ны биоиндикация тикшеренүләрендә кулланалар. Татарстан терр-ясендә еш очраучы төрләр: урман стафилины (Philonthus decorus), матур стафилин (Staphylinus caesareus), җирән стафилин (Oxyporus rufus). Киң стафилин (Velleius dilatatus) һәм йонлач стафилин (Emus hirtus) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Жизнь животных. Т. 3. Членистоногие: трилобиты, хелицеровые, трахейнодышащие. Онихофоры. М., 1984; Ш у л а е в Н.В. Фауна жуков — стафилинид (Coleoptera, Staphylinindae) Республики Татарстан (Предкамье): Подсемейство Oxyporinae, Steninae, Paederinae, Xantholininae, Staphylininae и Tachyporinae: Аннот. список видов. К., 2004.

*Н.В.Шулаев.*

**СТАХЕ́ЕВ** Дмитрий Иванович (14.2.1840, Вятка губ. Алабуга ш. — 14.3.1918, Ялта ш., Алушта шәһәрендә җирләнә), прозаик, шагыйрь, этнограф, журналист. И.И.Стахеев-


ның улы (к. *Стахеевлар*). 1854 елда әтисе киңәше б-н Кяхта шәһәренә (Кытай чигендә) күчеп килә, сәүдә б-н шөгыльләнә, 1858 дә 2нче гильдия сәүдәгәр була. «Иркутские губернские ведомости» г-тасына фельетоннар яза, «Кяхта елъязмасы» («Кяхтинская летопись», 1862) исемле мәкалә, «Амур станицасында тормыш» («Жизнь в Амурской станице», 1863) исемле очерк бастыра. Әдәбият б-н шөгыльләнү ниятеннән 1864 тә С.-Петербургка күчә. 1864–77 елларда «Искра», «Русское слово», «Будильник», «Отечественные записки», «Вестник Европы» ж-ллары, «Московские ведомости», «Русский мир» г-талары б-н хезмәттәшлек итә. «Нива» (1875) ж-лын, «Русский мир» (1876) г-тасын, «Русский вестник» (1896) ж-лын редакцияли. Император Рус геогр. җәмгыяте әгъзасы (1870 тән). 1905 тән Ялтада яши. Рус әдәбияты тарихына көнкүрешне сурәтләүче беллетрист, сәүдәгәрләр тормышын яхшы белүче язучы буларак кереп кала. «Варфоломей атакай» («Отец Варфоломей», М., 1872), «Илья Петрович Растеряев мирасы» («Наследство Ильи Петровича Растеряева», М., 1874), «Мәче» («Кот», М., 1876), «Сәнгать гыйбадәтханәсе янында» («У храма искусств», М., 1884) повестьларында, «Варислар» («Наследники», СПб., 1875), «Йорт учагы» («Домашний очаг», М., 1879), «Кояш баеганда» («На закате», М., 1881), «Табыш артыннан йөрү» («Походы на доходы», СПб., 1882), «Йөрәк сайлаган кеше» («Избранник сердца», СПб., 1884), «Студентлар» («Студенты», СПб., 1888), «Сүнмәс ут» («Неугасающий свет», СПб., 1893), «Күңелең сүрелмәсен» («Духа не угашайте», М., 1896) романнарында Мәскәү сәүдәгәрләре, Петербург эшмәкәрләре, галимнәр, язучылар, түрәләр, руханилар типлары күрсәтелгән. «Яңартылган гыйбадәтханә» («Обновлённый храм», 1890) романында, «Тырышып табылган» («Благоприобретение»), «Өяз шәһәре» («Уездный город»), «Базарда» («На базаре»), «Олаучылык. Кама күренешләре» («Извоз. Камские сцены») очеркларында Алабуга сәүдәгәрләре тормышы тасвирлана. Бурятлар, Себер һәм Амур буе өлкәләрендә яшәүче башка халыклар турында фәнни-популяр очерклар авторы. Әдәбият галиме В.В.Кожинов, С.ны Писемский, хәтта Гончаров дәрәҗәсенә күтәреп, «... ватаныбыз әдәбиятының классик исемнәре б-н бер рәттә торырга лаеклы», — дип яза («Мәдәниятләр гармониясе» — «Гармония культур», 2001).

Ә с ә р.: Сочинения: В 3 т. СПб., 1892; Собр. соч.: В 12 т. СПб., 1902–03.


*Әд.:* В а л е е в Н.М. Дмитрий Стахеев. Творческий путь писателя. К., 1995; ш у л у к. Стахеев Д.И. // Краеведы Елабуги. К., 2007.

*Н.М.Вәлиев.*

**СТАХЕ́ЕВЛАР**, Алабуга сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре. 19 йөздә — 20 йөз башында Россиянең атаклы сәүдәгәрләр династиясе, эре «Иван Стахеев һәм К° ширкәте» концернын гамәлгә куючылар. Ил сәнәгатен, сәүдәсен һәм шәһәр төзелешен үстерүгә зур өлеш кертәләр. С.ның нәсел сыйфаты — юмарт хәйриячелек: монастырьлар, чиркәүләр, уку һәм ятим балалар йортлары төзү, шәкертләр тәрбияләү, шәһәрне төзекләндерү б-н шөгыльләнәләр. Риваять буенча С. нәселенә нигез салучы кеше чыгышы б-н Новгород шәһәреннән була, 16 йөзнең 2 нче яртысында нығытылган болгар торулыгы урынында Трёхсвятское авылына (хәзер Алабуга ш.) нигез сала. Династияне башлап җибәрүчеләр — **Максим** С. (1730 — якынча 1795) һәм аның улы **Кирилл** (1760–1834), крәстияннәрдән. С.ның актив хуҗалык эшчәнлеге **Иван Кириллович** (1782–1836), аның уллары һәм оныклары исеме б-н бәйле. 1) **Иван Иванович** (1805–1885) — 1 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән килгән мактаулы граждан. Җирле сәүдә б-н шөгыльләнүче гади вак сәүдәгәрдән эшчәнлеге Вятка губернасы чикләреннән еракларга таралган миллионер-эшмәкәргә кадәр юл уза. Бөтен Себер буенча диярлек һәм Кытайда мануфактура товарлары, шикәр, икмәк б-н сәүдә итә. 2) **Дмитрий Иванович** (1818 — 6.1.1888) — 1 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән килгән мактаулы граждан, С. династиясе тарихында икенче сәүдәгәр-миллионер була. Гомере азагында аның капиталы 16 млн. сум тәшкил итә. Күмәртәләп икмәк, мануфактура һәм бакалея товарлары, чәй-шикәр сату б-н шөгыльләнә. 3) **Иван Григорьевич** (1837–1907) — 1 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән килгән мактаулы граждан, коммерция советнигы. Оештыру вакытында сәүдә капиталы 5 млн. сумга җиткән «Иван Григорьевич Стахеев» сәүдә йорты хуҗасы (1904). Төп эшчәнлеге Россиянең 23 шәһәрендә, ш.у. Финляндиядә алып барылган икмәк б-н сәүдә итүдән гыйбарәт була (Бөре, Түбән Новгород, Рыбинск, С.-Петербург, Чиләбе һ.б.). Фирманың сату өчен шактый зур күләмдә бөртекле ашлык җитештерүче 11 утары, ш.у. Иделдән алып Себергә кадәрге арада 26 ашлык сатып алу пункты була. Бөртекне эшкәртү, башлыча, 10 он тарту тегермәне, 3 аракы з-ды эшләгән Вятка һәм Уфа губерналары терр-ясендә туплана. Сәүдә йортының пароходчылыгында 7 буксир, 37 икмәк баржасы исәпләнә. Моннан тыш фирма үзенең нефть ташу флоты б-н дә җитәкчелек итә. Сәүдә эшендә әһәмияте буенча нефть икмәктән кала икенче урынны били. 1913 тә «Иван Григорьевич Стахеев» фирмасының нефть складлары резервуарлары сыйдырышлыгы 3245 мең пот тәшкил итә. 4) **Василий Григорьевич** (1842–1896) — 1 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән килгән мактаулы граждан, «В.Г.Стахеев варислары» сәүдә йортына нигез салучы һәм хуҗасы. Икмәк, мануфактура һ.б. товарлар б-н сәүдә итә. 1870 елларда Кама буендагы Дербешка авылы янында 100 гә якын пароход кышлый һәм ремонтлана торган суднолар төзәтү остаханәләренә һәм затонга ия була. Сәүдә йорты зур флот тота (1890 елларда — 4 пароходы һәм 40 лап зур көймәсе була). 5) **Иван Иванович**



И.Г.Стахеев.



И.И.Стахеев.



Г.Ф.Стахеева.

(1869 — ?) — династиянең иң күренекле һәм талантлы вәкилләреннән берсе; 1913 тә П.П.Батолин б-н берлектә Кама-Себер нефть сәнәгате акц. җәмгыятен оештыра. Пай кертү нигезендә икмәк сату б-н шөгыльләнүче «Иван Стахеев һәм К°» ширкәтенә (1912) милектәш (П.П.Батолин б-н берлектә) була (1913 тә ширкәт капиталы 3 млн. сум тәшкил итә). 1916 да А.И.Путилов һәм П.П.Батолин б-н берлектә Россиядә иң эре монополистик берләшмә — Стахеев концернын төзи (1917 дә төп оешманың балансы 300 млн. сумга, гомуми әйләнеш суммасы 1 млрд. сумга якын). 6) **Фёдор Васильевич** (1870–1945) — инженер-механик, Россиянең Дәүләт советы әгъзасы. С. сәүдә йорты пр-тиеләре өчен биналар проектлый һәм төзи. 1902 дә Алабугада электр станциясе кора, нәтиҗәдә, Россиянең шәһәр урамнары электр уты белән яктыртылучы беренче 10 шәһәре исәбенә керә; 1901 дә пар б-н эшләүче сууткәргеч төзелә. 1920 елларда Америкага китә. 7) **Глафира Фёдоровна** (1847–1927) — нәселдән килгән мактаулы граждан, Василий Григорьевичның хатыны. Епархия кыз-балалар уч-щесе бинасы төзелешенә 400 мең сум акча иганә кыла, аны 1917 елга кадәр үз хисабына тота (хәзер Алабуга пед. ун-тының уку корпусы). Окт. рев-циясеннән соң калган гомерен Алабугадагы Казан Богородица хатын-кызлар монастырендә үткәрә.

1917–19 да С.ның сәүдә һәм сәнәгать пр-тиеләре дәүләт милкенә күчерелә. С. династиясе вәкилләре хәзерге вакытта Россия, Англия, Австралия, Франция, Швейцария, Сингапур һ.б. илләрдә яшиләр. С.ның хәйрия эшчәнлекләре масштабы турында документлар буенча фикер йөртергә мөмкин; мәс., 1892 дә хәйриячелек максатында тотылган капиталның процент акчасы гына да 986400 сум тәшкил итә. Гомумән, «Хәйрияче граж-



Стахеевларның Алабуга шәһәрендәге табыш йорты. 19 йөз уртасы.



В.Т.Степанов.

даннар Д.И. һәм И.И.Стахеевлар комитеты» 1876 дан 1917 гә кадәр хәйриячелек эшләренә уннарча млн. сум акча сарыф итә, моның өчен династия вәкилләренең купчелеге Россия империясенең орденнары һәм медальләре б-н бүләкләнә. Ш.у.к. *Д.И.Стахеев.*

*Әд.:* В а л е е в Н.М. Роль купеческой династии Стахеевых в судьбах России // Науч. Татарстан. 2004. № 12; В а л е е в Н.М., В а л е е в а Н.Г. Елабуга-Харбин-Сидней. К., 2007.

*Н.М.Вәлиев.*

**СТАШЕ́ВСКИ** Зенон (13.10.1972, Литва ССРның Вильнюс ш.), биолог, биол. фән. канд. (2010), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Вильнюс пед. ун-тын тәмамлый (1996). 1996–98 елларда А.х. биотехнологияләре үзәгендә (Венгрия, Геделе ш.). 1998–2000 дә Литва ФАнең Ботаника ин-тында. 2000 нән Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында. Дәүләт бүләге ТРда сәламәтләндерелгән нигездә бәрәңге орлыкчылыгы системасын эшләгәне һәм гамәлгә кертүе өчен бирелә.

**СТЕКО́ЛЬНЫЙ** посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 48 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тимерлек елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 1 кеше яши. 1910 елларда оештырыла. 1920 еллардан рәсми чыганакларда 2 торак пункт — Стекольный һәм Стекольный Завод, 1930 еллардан Югары Стекольный һәм Түбән Стекольный (1964 нең 23 апрелендә бер торак пункт булып берләшә) буларак исәпләнә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Әлмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1920 дә — 219, 1926 да — 187, 1938 дә — 342, 1949 да — 339, 1958 дә — 372, 1970 тә — 429, 1979 да — 163, 1989 да — 17, 2002 дә — 3 кеше.

**СТЕПА́НОВ** Алексей Иванович (26.2.1943, Казан — 20.9.2010, шунда ук), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002), ТРның атказ. машина төзүчесе (2000). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1966). 1965–92 елларда Казан «Ми-Вертолётлар» фәнни-җитештерү пр-тиесендә эшли: өлкән техник-конструктор, инженер-конструктор, әйдәп баручы конструктор, әйдәп баручы конструкторлар бүлегендә төркем җитәкчесе (1980 нән). 1992–2010 да «Казан вертолёт заводы» АҖдә: баш конструктор урынбасары, АҖнең Баш конструктор идарәсе башлыгы (1994 тән). С. җитәкчелегендә «Ансат» күп максатлы җиңел вертолёты, «Актай» җиңел вертолёты эшләнә. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Дәүләт бүләге модернизацияләнгән Ми-8МТВ-1, Ми-8МТВ-2, Ми-8МТВ-3, Ми-8МТВ-5, Ми-172 вертолётларын һәм аларның модификацияләрен серияләп җитештерүгә куйганы өчен бирелә.

**СТЕПА́НОВ** Владимир Павлович (1.10.1930, Казан — 15.5.2004, шунда ук), геофизик, геол.-минерал. фән. д-ры (2002), ТАССРның атказ. геологы (1990). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1954), Казан геофизика экспедициясендә эшли. 1983 елдан ТатНИПИнефтьтә, 1994 тән Татарстан геол. разведка идарәсендә. Хезмәтләре геофизика һәм тектоникага карый. С. кристаллик нигезнең тектоник төзелешен өйрәнүдә геол.-геофизик материалларны комплекслы аңлату методикасын эшли. Татарстан һәм чиктәш төбәкләр өчен Җир кабыгының нигез өслеге, җимерелүләре һәм терр-яләрне районлаштыру карталарын төзи. Идел буенда утырма токымнар һәм нигезнең коллектор зоналарында нефть перспективаларын нигезләүдә катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Кольцевые структуры земной коры Волжско-Камской антеклизы. К., 1983 (автордаш); Кристаллический фундамент Татарстана и проблемы его нефтегазоносности. К., 1996 (автордаш).

*Әд.:* Памяти Степанова Владимира Павловича // Георесурсы. 2006. № 1.

**СТЕПА́НОВ** Владимир Тимофеевич (9.8.1930, Новосибирск ш. — 20.3.1998, Түбән Новгород ш.), җырчы (баритон), ТАССРның халык артисты (1974). Саратов консерваториясен тәмамлаганнан соң (1957), С.Айни исем. Таҗик опера һәм балет театрында, 1958 елдан — Абай исем. Казакъ опера һәм балет театрында, 1959–61 дә — Новосибирск опера һәм балет театрында, 1967–71 дә Ульянов филармониясендә эшли. 1961–67 дә һәм 1971–74 тә — Татар опера һәм балет театрында, 1974 тән Горький опера һәм балет театрында солист. 1991 дә яңа оешкан Түбән Новгород опера һәм муз. комедия камера театрын җитәкли (1999 да С. исеме бирелә). Татар опера һәм балет театрында башкарган партияләре — Фигаро («Севилья чәчтарашы», Дж. Россини), Риголетто, Ренато, Амонасро («Риголетто», «Бал-маскарад», «Аида», Дж. Верди), Валентин («Фауст», Ш.Гуно), Эскамильо («Кармен», Ж.Бизе), Скарпиа («Тоска», Дж. Пуччини), Онегин, Елецкий, Роберт («Евгений Онегин», «Пики дамасы», «Иоланта», П.Чайковский), Грязной («Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков) һ.б. Концерт эшчәнлеге алып бара (репертуарында — Көнбатыш Европа һәм рус вокал классикасы әсәрләре, хәзерге заман композиторларының эстрада җырлары).



В.Т.С т е п а н о в  Грязной ролендә («Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков).

*Р.И.Такташ.*

**СТЕПА́НОВ** Яков Спиридонович (22.10.1831, Вятка губ. Яранск ш. — 1.10.1891, Казан), хокук белгече, полиция хокукы д-ры (1869), хакыйкый статский советник (1874). Дворяннар катлавыннан. Казан ун-тын тәмамлый (1855). 1857–58 елларда Сембер дворян депутатлар җыены чиновнигы. 1858–61 дә Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе өлкән укытучысы. Бер үк вакытта, 1858 дән, Казан ун-тында, 1861–67 дә адъюнкт, 1867–69 да доцент, 1869–70 тә экстраординар проф., 1870–86 да ординар проф., 1886 дан полиция хокукы каф. атказ. профессоры. С.ның «Франциядә, фән буларак, полиция турында» («О полиции, как науке, во Франции», 1867), «Англиядә, фән буларак, полиция турында» («О полиции, как науке, в Англии», 1868), «Германиядә полиция турындагы фәннең мөстәкыйль гамәлдә булуының беренче ике чоры» («Первые два периода самостоятельного существования науки о полиции в Германии», 1869) монографияләре 18–19 йөзләрдә Көнбатыш Европа илләрендә «полиция фәне»нең барлыкка килүе һәм үсеше мәсьәләсенә багышлана. «Университетлар уставын яңадан карау уңаеннан» («По поводу пересмотра устава университетов», 1878), «Англия, Франция, Германия һәм Австрия университетларында төзелеш һәм идарә системасы» («Устройство и управление университетов в Англии, Франции, Германии и Австрии», 1878) хезмәтләрендә юридик белем бирүнең Европа, барыннан да бигрәк, инглиз системасын тәкыйтьләп чыга. Казан ун-тының юридик ф-ты каршындагы махсус китапханәне оештыручы була.

Х е з м.: Наше законодательство о мерах против чумы, а «также повальных и заразительных болезней» вообще. К., 1879; Замечания на третью главу проекта уголовного уложения. К., 1886.

*Әд.:* И в а н о в с к и й В.В. Яков Спиридонович Степанов: Некролог // Уч. зап. Казан. ун-та. 1891. Кн. 6; Биогр. словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**СТЕПА́НОВА** Альбина Ивановна (12.12.1935, Казан — 14.3.2009, Пермь ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1982), проф. (1986), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1993), РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1977). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1958), Пермь полимер материаллар фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, лаб. башлыгы (1970 елдан), бүлек башлыгы (1973 тән). 1987–2000 дә Казан энергетика ун-тында, химия (1990 нан), су һәм ягулык технологиясе (1998 дән) ка-

федралары мөдире, җылылык энергетикасы ф-ты деканы (1995–2000). 2000 нән «Уретанмаш» фәнни-җитештерү пр-тиесе директоры (Пермь ш.). Хезмәтләре нәорганик ачыткычлар нигезендәге композицион һәм полимер материаллар химиясенә һәм технологиясенә карый. С., рецептуралар проектлауның хисап-тәҗрибә алымнарын, ш.у. төзеләчәк материалның эксплуатацион параметрларын билгели торган нәзек структур һәм химик механизмнар турында яңача карашларны кулланып, перспектив композицион полимер материаллар ясау принципларын эшли. Катализ һәм куертылган системалар янганда ультрадисперс халәттәге ачыткыч кулланылган ингибирлау теориясен үстерә. Сыек тирәлекләрдә ультрадисперс халәттәге нәорганик шартлаучан ачыткычлар технологиясенең фәнни-методик нигезләрен тәкъдим итә. С. җитәкчелегендә нефть скважинасының забой алды зонасына аның продуктлылыгын күтәрү максатыннан термогазохимик тәэсир итү өчен җылыга чыдам дарылар һәм махсус җайланмалар (скважиналар өчен басым аккумуляторы — АДС) уйлап табыла. Югары басым һәм скважина сыеклыгы шартларында 3 *км* дан артык тирәнлектәге нефть ятмалары өчен җылыга чыдамлыгы озак вакытка исәпләнгән АДСлар (200–300 °С та 24 сәгатькә кадәр) эшләнә. С.ның фәнни эшкәртмәләре оборона техникасында, халык хуҗалыгында (герметиклар, шпатлёвкалар, киң ассортиментта лаклар һәм буяулар, уретан һәм полиуретан эластомерлар, пенополиуретаннар) кулланылыш таба. 300 фәнни хезмәт авторы. Уйлап табуга 150 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1978). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Выпускники — гордость технологического университета. КХТИ — КГТУ (1931–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**СТЕПА́НОВА** Наталья Владимировна (27.4.1965, Кукмара р-ны Лубян пос.), гигиена белгече, мед. фән. д-ры (2005). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1988), шунда ук балалар һәм яшүсмерләр гигиенасы кафедрасында калдырыла, 2002 елдан хезмәт гигиенасы (медэкология курсы б-н) кафедрасында. Хезмәтләре балаларга мед. ярдәме күрсәтүне оештыруга, балалар һәм яшүсмерләр хезмәт эшчәнлегенең гигиена нормаларын билгеләүгә, балалар учреждениеләренә эпидемиологик тикшерүләр уздыруга карый.

Х е з м.: Влияние загрязнения атмосферного воздуха на показатели внешнего дыхания детского организма // Актуальные экологические проблемы РТ. К., 2000; Гигиеническое нормирование трудовой деятельности детей и подростков. К., 2001.

**СТЕПА́НОВКА** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 44 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шомбыт елгасыннан 2 *км* ераклыкта урнашкан. Даими яшәүчеләр юк. 19 йөз башында Сембер губернасының Языково авылыннан күченүчеләр нигез сала. 1861 гә кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.да чиркәү-приход мәктәбе (1891 дә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 49,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1859 да — 211, 1897 дә — 302, 1908 дә — 365, 1920 дә — 291, 1926 да — 296, 1938 дә — 323, 1949 да — 170, 1958 дә — 188, 1970 тә — 129, 1989 да — 29, 2002 дә — 14 кеше.

**СТЕПА́НОВКА** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 8 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казан–Ульянов автомобиль юлы буенда. 2010 елда 117 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, китапханә. 18 йөзнең 1 нче чирегендә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Мельничная Карланга исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт һәм алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.да чиркәү-приход мәктәбе (1890 да ачыла), 1 су һәм 2 җил тегермәне, тимерчелек, 3 вак-төяк-ләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 991 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Зур Фролово волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 68 ир-ат; 1859 да — 415, 1908 дә — 995, 1920 дә — 831, 1926 да — 688, 1938 дә — 741, 1949 да — 413, 1958 дә — 286, 1970 тә — 178, 1979 да — 135, 1989 да — 120, 2002 дә — 137 кеше.

**СТЕПА́НОВКА** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 20 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Камышлы елгасының (Ыкның сул кушылдыгы) югары агымы буенда. 2010 елда 57 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, китапханә. 18 йөз ахырында алпавыт С.Н.Можаров нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Харькевич, Харьковщина исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, авыл җәмәгатенең имана җире 193 дис. тәшкил итә. 1911 дә әвенле җил тегермәне эшли. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Матвеевка волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 21, 1811 дә — 62, 1859 да — 90, 1870 тә — 104, 1884 тә — 212, 1897 дә — 154, 1906 да — 187, 1913 тә — 197, 1920 дә — 181, 1926 да — 203, 1938 дә — 187, 1949 да — 93, 1958 дә — 87, 1970 тә — 340, 1979 да — 215, 1989 да — 53, 2002 дә — 71 кеше.

*Әд.:* Мензелинский край: История и современность. Мензелинск, 2006.

**СТЕ́ПИН** Сергей Николаевич (20.4.1949, Кисловодск ш.), химик-технолог, химия фән. д-ры (1996), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2002). 1971 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, лаклар һәм буягычлар технологиясе каф. мөдире (1997 дән). Хезмәтләре тутырылган полимерлар физик химиясенә карый. С. лакка буялган пигментлы системаларның эксплуатация характеристикаларын көйләүнең коллоидлы-химик принципларын эшли. Лаклы буяу б-н капланган металларның коррозия дәрәҗәсен билгеләү ысулын тәкъдим итә. Коррозиягә каршы манганитлар нигезендәге пигментларның яңа классын таба һәм тикшерә. Уйлап табуга 20 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Неорганические пигменты. СПб., 1992 (автордаш); Исследование адсорбции и определение характеристик адсорбционного слоя в наполненных растворах полимеров // Журн. прикладной химии. 1993. Т. 66, № 4 (автордаш); An Investigation of the Interphase Interactions in the Polymer Composites by Using IR-Spectroscopy Method // Journal of Molecular Structure. 1995. V. 348 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**СТЕРЕОХИ́МИЯ**, химиянең бер бүлеге, молекулаларның фәзаи төзелешен һәм аның матдәләрнең физик һәм химик үзлекләренә тәэсирен өйрәнә. Молекулаларның күпчелеге өч үлчәнешле төзелгән, шунлыктан химиянең һәм аңа якын фәннәрнең (биохимия, молекуляр биология) барлык өлкәләрендә С. алымнары кулланыла. С. мөмкин дип табылган стереоизомерларны (составы һәм химик төзелеше бер үк, ләкин атомнарының фәзада урнашуы б-н аерыла торган молекулалар) билгели, аларның архитектурасын, энергетик һәм физик (аерым алганда, спектраль) характеристикаларын таба, стереоизомерларның үзара әверелешләрен дә кертеп, химик реакцияләргә стереохимик таләпләрне һәм әлеге реакция нәтиҗәләрен ачыклый. Медицинада, а.х.да һәм халык хуҗалыгының башка тармакларында кулланылыш тапкан стереоизомер матдәләрнең биол. активлыгын исәпкә алып, саф изомерлар, ш.и. оптик актив катнашмалар (асимметрик синтез) табу һәм анализлау алымнарын булдыруга зур әһәмият бирелә.

С.гә француз химигы Л.Пастер нигез сала (1848), ул шәраб к-тасы кристалларының оптик активлыгындагы үзгәлекләрнең (сулга һәм уңга әйләндерүче) ике асимметрик форма булуга бәйле икәнен күрсәтә. Ул оптик изомерларны (энантиомерларны) аларның берсен үзләштерә торган микроорганизмнар ярдәмендә аеру мөмкинлеген ачыклый.

Изомерия турындагы заманча карашларны А.М.*Бутлеров* нигезли (1861). В.В.*Марковников*, беренчеләрдән булып, стереоизомерия күренешен изомер молекулаларның физик үзлекләрендәге аерымлыклар б-н бәйли. Стереохимик тикшеренүләр РФА КҮНнең Органик һәм физик химия ин-тында, Казан ун-тының А.М.Бутлеров исем. Химия ин-тында

алып барыла. Б.А.*Арбузов* җитәкчелегендә конформацион анализ буенча хезмәтләре б-н Казан химия мәктәбе галимнәре С. үсешенә зур өлеш кертәләр (А.Н.*Верещагин*, С.Г.*Вульфсон*, В.А.*Наумов*, Л.К.*Юлдашева*, Р.П.*Аршинова*, И.А.*Литвинов*, Э.А.*Ишмаева*, Е.Н.*Климовицкий*, Г.А.*Чмутова*, И.И.*Пацановский*, В.Е.*Катаев*, Э.Х.*Казакова* һ.б.). Мышьяк С.сен өйрәнүдә Г.Х.*Камай* зур роль уйный. И.Ә.*Нуретдинов*, беренче булып, саф энантиомер селенофосфон к-таларын таба; Штаудингер һәм Перков стереохимик реакцияләрен өйрәнә. Конформерларның реакциягә сәләтен реакция нәтиҗәсендә хасил булган диастереомерлар нисбәтенә бәйли торган яңа алымнар системасы эшләнә (Е.Н.Климовицкий, Ю.Г.Штырлин). РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эремәләрдә хираль кушылмаларның абс. конфигурациясен ачыклау (Ш.К.*Латыйпов*), фосфорорганик кушылмаларны энантиоселектив синтезлау (В.А.*Альфонсов*, А.А.Карасик, М.А.*Пудовик*, О.Г.*Синяшин*), рацематларны кристаллашу вакытында таркатуга нигезләнеп, саф энантиомер физиол. актив кушылмалар табу (А.А.*Бредихин*, З.А.*Бредихина*) эшләре алып барыла.


*Әд.:* Б ы к о в Г.В. История стереохимии органических соединений. М., 1966; К и п е р т Д. Неорганическая стереохимия. М., 1985; И л и е л Э., В а й л е н С., Д о й л М. Основы органической стереохимии. М., 2007.

*А.А.Бредихин.*

**СТЕ́ФАН** (? — 1552, Казан), Рус православие чиркәвенең газап күргән изгесе; Арча ягы татары (чын исеме билгесез). С. дистәләрчә ел дәвамында аягы сызлаудан интегә; Гайсәгә иман китергәннән соң, савыгу таба. 1552 елда чукындырыла. Шул ук елда, казанлыларның Шаһгалигә каршы фетнәсе вакытында, качарга мөмкинлеге булуга карамастан, С. Казанда кала. Фетнәчеләр тарафыннан җәзалана. 1592 дә Казан һәм Әстерхан митрополиты Гермоген башлангычы б-н изгеләштерелә. Рус православие чиркәве тарафыннан иске стиль б-н 27 мартта (яңача 6 апрельдә) җәфа күргән *Пётр* б-н бергә искә алына.

*Әд.:* Жития святых мучеников Казанских Иоанна, Петра и Стефана. К., 2001.

**СТЕФАНО́ВСКИЙ** Геннадий Алексеевич (8.10.1918, Вятка губ., Вятка өязе Пасегово а. — 7.4.1991, Әлмәт ш.), рәссам, педагог, ТАССР, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1976, 1987). Киров шәһәрендәге сәнгать студиясен (1937), Н.К.Крупская исем. Мәскәү мәдәният ин-тын (1969) тәмамлый. Ростов шәһәрендәге (Ярославль өлкәсе) клуб учреждениеләрендә рәссам, «Киров рәссамы» ширкәтендә график-рәссам булып эшли. 1945 елдан Буа мәдәният йорты директоры, 1948 дән — рәссамы, 1951 дән шәһәр тибындагы Урыссу посёлогында сәнгать мәктәбендә сызым һәм рәсем дәресләре укыта. 1957 дән Әлмәттә яши, 10 нчы урта мәктәптә эшли, 1966–82 дә 1 нче балалар сәнгать мәктәбе директоры. С. башлангычында 1975 тә мәктәп каршында өлкәннәр өчен кичке бүлек ачыла һәм Картиналар галереясы төзелә (1982–87 дә аның директоры була). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1969). Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәкләрендә заманча сынлы сәнгать нигезләрен салган беренче проф. рәссамнарның берсе. Төп жанры — Кама аръягы ландшафтларын, авыл күренешләрен сурәтләгән табигый һәм индустриаль пейзаж: «Нефтьле Татарстан» (1969), «Нефть хәзинәсе» (1978), «Сөләй таулары» (1978), «Буровой», «Татарстан киңлекләре», «Камада», «Март», «Соңгы кар» (барысы да — 1970 еллар). Натурадан төшерелгән этюдлар С. иҗатында зур урын алып тора: «Тын кич», 1969), «Урсала» (1977), «Яңгырдан соң», «Иртәнге таң» (икесе дә — 1978), «Бигәш», «Урсала күренеше», «Зәй елгасында» (барысы да 1970 еллар). 1980 елларда рәсем («Генерал Рыжиков», «Ларин портреты», «Гариф Ахунов», «Автопортрет») һәм скульптур («Журналист») портрет жанрларында эшли. Әлмәтнең сәнгати бизәлеше авторларының берсе; Буада һәм Апаста В.И.Ленинның монументаль һәйкәлләрен төзүдә катнаша, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогында В.И.Ленин һәйкәле проекты авторы (1970–80 еллар). Вакытлы матбугатта сынлы сәнгатьне актив пропагандалый.



Г.А.С т е ф а н о в с к и й. «Татар җире киңлекләре». 1978.

Әлмәттә һәм ТАССРның көньяк-көнчыгышындагы башка төбәкләрдә уздырылган сәнгать күргәзмәләрендә катнаша (1960 еллардан). Шәхси күргәзмәләре Әлмәттә уздырыла (1978, 1998).

Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Чаллы, Әлмәт картиналар галереяларында саклана.

Бөек Ватан сугышы ветераны. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Әлмәттәге Картиналар галереясы бинасында мемориаль такта урнаштырыла. С.ның портреты рәссам А.Ә.Абызгилдин тарафыннан башкарыла.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**СТИЛИ́СТИКА** (лат. stylus — язу нигезе), тел белеменең телдәге стильләр системасын, сәнгатьчә чараларны сөйләм теленең төрле өлкәләрендә куллану закончалыкларын өйрәнүче тармагы. С.ның төп предметы — стиль, ягъни теге яки бу сүзнең кайда, кайчан һәм нинди максат б-н әйтелүеннән (язылуыннан) чыгып, фикер һәм хис-кичерешләрне телдән җиткерүнең билгеле бер формасы. Татар тел белемендә стильләр турындагы беренче мәгълүматлар 19 йөзгә карый. Татар телен беренчеләрдән булып өйрәнүче М.Иванов телдә 2 стильне аерып карый (аларны язма тел һәм сөйләм теле дип атый). К.Насыйри татар язма теленең артта калганлыгын билгеләп үтә һәм аны демократлаштырырга, сөйләм теленә якынайтырга кирәклеген басым ясый. С.Кукляшев тарафыннан татар тел белеменә өч стиль теориясе кертелә. «Татар хрестоматиясе» («Татарская хрестоматия», 1859) хезмәтендә ул татар текстларының бертөрле генә булмаулары һәм аларны 3 стилистик төргә (гади тел, эш кәгазьләре теле, фәнни тел) берләштерергә мөмкинлеге турында яза. «Стиль» термины татар тел белеменә Н.Ф.Катанов тарафыннан кертелә. Фән буларак татар С.сы 1950 еллар башында барлыкка килә һәм галим Л.Җәләй эшчәнлеге б-н бәйле була. Аның укучылары Ф.С.Фасиев, Х.Р.Курбатов, В.Х.Хаков, С.М.Ибраһимов, И.Б.Бәширова һ.б.ның хезмәтләрендә татар теленең хәзерге татар С.сында кабул ителгән функциональ стильләре классификациясе бирелә: әдәби, фәнни, рәсми эш кәгазьләре (рәсми-канцелярия), публицистик, эпистоляр. **Әдәби стиль** (матур әдәбият стиле) өчен әдәби телдәге барлык сурәтләү чараларын да файдалану хас. Анда укучыга эмоциональ яктан тәэсир итәрдәй гади сөйләм сүзләре дә, диалектизмнар, жаргон сүзләр дә очрый. **Фәнни стильнең** төп үзенчәлекләре булып гомумилек, катгый эзлеклелек, төгәллеккә һәм ачыклыкка омтылу тора. Бу стильдә фәнни мәкаләләр, чыгышлар (докладлар), монографияләр, фәнни хезмәтләр (диссертацияләр) языла, фәнни бәхәсләр алып барыла. Әлеге стильнең 3 төре аерып күрсәтелә: саф фәнни, фәнни-уку-укыту һәм фәнни-популяр. **Рәсми эш кәгазьләре стиленә** җыйнаклык, материалның бер калыпка салынган, тиешле формада булуы, эмоциональ-экспрессив тел чаралары файдаланылмау, рәсмилек хас; эшлекле мөнәсәбәтләр өлкәсендә кулланыла. Ул үз эчендә дипломатик (халыкара килешүләр, ноталар, гаризалар, рәсми белдерүләр һ.б.), законнар чыгара торган (конституция, законнар, гражданлык һәм җинаятьчелек актлары, указлар, кодекслар, уставлар) һәм адм.-канцелярия (чакыру кәгазьләре, белдерүләр, боерыклар, күрсәтмәләр, эшлекле хатлар һ.б.) төрләренә бүленә. **Публицистик стильне** барлыкка китерүче төп үзенчәлекләр булып бәя бирү һәм эмоциональлек тора. Гаммәви коммуникация текстларында — периодик басма, радио, телевидениедә кулланыла. Бу стиль мәгълүмати (кыска мәкалә, репортаж, отчёт, интервью, хроника, күзәтү) һәм аналитик (мәкалә, шәрехләмә, рецензия, күзәтү) жанрлар өчен хас; әдәби-публицистик жанрлар (очерк, фельетон) стиле ягыннан аеруча әдәби әсәрләргә якын тора. **Эпистоляр стильдә** кешеләр арасындагы шәхси һәм туганлык мөнәсәбәтләре чагыла. Бу стильне татар әдәби тел стильләре системасына кертеп карау мәсьәләсе бәхәсле: кайбер галимнәр (В.Х.Хаков, С.М.Ибраһимов, И.Б.Бәширова) аны мөстәкыйль стиль буларак карыйлар, кайберләре исә (М.З.Зәкиев, Х.Р.Курбатов), кулланылыш дәрәҗәсенең чикле булуына һәм башка стильләр (рәсми эш кәгазьләре, сөйләм) б-н охшашлыгына басым ясап, аны функциональ стильләр системасына кертмиләр.

*Әд.:* К у р б а т о в Х.Р. Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы. К., 1971; ш у л у к. Татарская лингвистическая стилистика. М., 1978;

И б р а һ и м о в С.М. Синтаксик стилистика. К., 1989; Х а к о в В.Х. Татар әдәби теле (стилистика). К., 1999; Б ә ш и р о в а И.Б. Хәзерге татар әдәби телендә фәнни әдәбият стиле: Гомуми мәгълүмат // Фән һәм тел. 2000. № 3.

*А.Ф.Йосыпов.*

**СТО́ГНИЕВ** Иван Данилович (21.12.1941, Ворошиловград өлкәсенең Старобельск р-ны Подгоровка а.), генерал-майор (1991), РФнең атказ. хәрби белгече (1998). Одесса югары гомумгаскәри командирлар уч-щесен (1963), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (Мәскәү, 1971) тәмамлый. 1963–76 елларда Совет Армиясендә командир вазифаларында (Приморье һәм Ворошиловград өлкәләре). 1976–78 дә Йәмән Халык Демократик Респ-касында пехота бригадасы командирының хәрби киңәшчесе. 1978–86 да Одесса югары берләштерелгән хәрби уч-щесе башлыгы урынбасары. 1986–88 дә Әфганстан Респ-касында Хәрби ун-т башлыгының хәрби киңәшчесе. 1989–99 да ТАССРның хәрби комиссары, Казан гарнизоны башлыгы. 1999–2002 дә ТР Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында эшли. 2002 дән «Хәрби-мемориаль гарантия» АҖнең генераль директоры. Кызыл Йолдыз, Халыклар дуслыгы, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**СТО́ЙКОВ** Иван Иванович (28.5.1972, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (2008). 1994 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. Хезмәтләре супрамолекуляр химиягә карый. С. каликс[4]арен һәм аның тиа-аналогының гетероциклик, ароматик һәм элементорганик функциональ төркемнәр кергән алыштыргычлы кушылмаларын синтезлый. Каликсарен нигезендәге рецепторлар синтезлауның бәйләү үзәкләренең өч үлчәнешле оешу үзенчәлекләрен саклый һәм синтезның югары стереосайланышын тәэмин итә торган юлларын тәкъдим итә. Тиакаликс[4]ареннарда функциональ төркемнәрне һәм алыштыргычларны сайлап алу юлы б-н ион парларының стехиометрик составын һәм сайланышлы формалашуын, рецепторларның фәзаи төзелешен билгели торган факторларны ачыклый. Күп кенә органик к-талар һәм аларның анионнары өчен югары сайланышлы мембрана күчергечләр, ш.у. күпсанлы субстратларны каликс[4]ареннар нигезендәге синтетик рецепторлар б-н бәйләүнең нәтиҗәлелеген һәм үзенчәлеклелеген билгели торган критерийлар һәм таләпләр эшли. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008).

Х е з м.: Начала супрамолекулярной химии. К., 2001; Введение в хроматографические методы анализа. К., 2003 (автордаш); Искусственные ионные каналы // Успехи химии. 2003. Т. 72, № 12 (автордаш).

**СТОЛБИ́ЩЕ** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 17 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кавал күле янында урнашкан. 2010 елда 4018 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 66%, татарлар — 31%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык; «Таткабель», сөт з-дларында эшлиләр. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Чиркәү. Рус чыганакларында 1565–67 еллардан Починок Федков (Починок Федотов) буларак билгеле, хәзерге исемен 17 йөз башыннан йөртә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Гурьево атамасы б-н дә мәгълүм. Халкы башта Казан архиерей йортына карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, он тарту һәм тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе, этап йорты урнаша. Изге Гурий чиркәве (1825 тә төзелә), земство мәктәбе (1843 тән эшләүче авыл приход мәктәбе җирлегендә 1869 да ачыла), фельдшерлык пункты, 2 тимерчелек, крахмал з-ды, 10 җил һәм 2 нефть двигательле тегермән, атлы почта станциясе, 2 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 8 вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2711,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Столбище волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-ннарында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище р-ны үзәге, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 236 ир-ат; 1859 да — 849, 1897 дә — 1347, 1908 дә — 1475, 1920 дә — 1332, 1926 да — 1751, 1949 да — 1176, 1958 дә — 1740, 1970 тә — 2445, 1979 да — 2626, 1989 да — 2872, 2002 дә — 3641 кеше.

**«СТОЛБИ́ЩЕ»**, Лаеш р-нындагы а.х. пр-тиесе. 1960 елда ремонт-техника станциясе һәм «Красноармеец» (Столбище а.), «Красный Маяк» (Рогозино а.), «Волга» (Комлы Кавал а.), «Прожектор» (Никольский а.), «Искра» (Сапуголи (Сабакүл), «Борьба» (Олы Кабан), «Восход» (Олы Отар), «Комсомолец» (Чемерцы а.) к-злары җирлегендә оештырыла. 1960 тан Татарстан Респ-касы а.х. тәҗрибә станциясе карамагында була. 1964 тә Никольский һәм Кавал бүлекләре җирлегендә мөстәкыйль «Волжский» һәм «Казан» с-злары оештырыла. 1969 дан «С.» Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты карамагында. 1975 тә Сокуры бүлеге җирлегендә Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының мөстәкыйль Үзәк эксперименталь базасы оештырала. 1976–2005 тә «С.» составына Столбище, Олы Кабан, Кече Кабан авыллары керә. Эшләүчеләр саны — 164 кеше (2004). А.х. файдалану җирләренең мәйданы — якынча 5 мең *га*, ш.и. 4,6 мең *га* сөрүле җирләр. Төп тармагы — бөртеклеләрнең сортлы элита орлыгын, бөртекле-кузаклы һәм ярма культуралары, күпьеллык үләннәр, бәрәңге, сөт җитештерү. Уртача еллык бөртекле ашлык җитештерү 4 меңнән алып 6 мең *т* га кадәр, бөртеклеләрнең уңышы 1 *га* дан 52,6 *ц* га җитә (1997), бәрәңгенеке — 250 *ц* (1992); бөртекле культуралар орлыгын (элита, 1 нче репродукция) сату — 1,7 мең *т*, бәрәңгенеке — 400 *т*. 100 *га* а.х. файдалану җирләренә 450–610 *ц* сөт җитештерелә. Җитештерүнең табышлылык дәрәҗәсе 39% тәшкил итә (1992). Хуҗалык берничә тапкыр КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКларының Мактау грамоталары, дипломнар һәм күчмә Кызыл байрагы б-н бүләкләнә. Хуҗалык үсешенә иң күп өлеш кертүчеләр — Д.К.Каюмов (1970–76), Г.Х.*Вәлиуллин* (1976–2001). 2004 тә пр-тие зыянга эшли башлый, 2005 тә банкротлык процедурасын узганнан соң ябыла, аның терр-ясе «Алтын башак» а.х. предприятиесе» ҖЧҖ составына кертелә.

*Әд.:* Мизгелләр елъязмасы — Летопись мгновений. К., 2000.

*И.Н.Афанасьев.*

**СТОЛБИ́ЩЕ АУЧЫЛЫ́К ТЫЮЛЫГЫ́**, Иделнең уңъяк яры буенда. Лаеш р-ны терр-ясендә урнашкан. Зур тиен — телеутканы (*гади тиеннең* астөре) климатка яраклаштыру максатыннан 1963 елда оештырыла. Мәйданы 5,2 мең *га*, ш.и. урманнар 4,8 мең *га*. Поши, төлке, бурсык, сусар, Америка чәшкесе, ак куян очрый. 2003 тә бетерелә.

*Р.Э.Чистяков.*

**СТОЛБИ́ЩЕ КҮЛЕ́**, к. *Хәерби күле*.

**СТОЛБИ́ЩЕ РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1938 елның 4 августында оештырыла. Үзәге — Столбище а. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан һәм Лаеш өязләренә, 1920 дән ТАССРның Арча һәм Лаеш кантоннарына, 1927 дән Казан авыл һәм Лаеш, 1930 дан болардан тыш Питрәч р-нына керә. 1940 та С.р.ның мәйданы — 958 *км*², халык саны — 32,5 мең кеше, 23 авыл советы, 78 торак пункт була. 1956 да район 936,3 *км*² җир били, аңа 21 авыл советы, 81 торак пункт керә. 1959 ның 26 мартында С.р. таркатыла, терр-ясе Биектау, Лаеш һәм Питрәч р-ннарына бирелә.

**СТО́ЛОВ** Евгений Львович (25.6.1944, Казан), математик, техник фән. д-ры (1993), проф. (1994). 1965 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (бүленеп), гамәли матем. (1993–2001), системалы анализ һәм информацион технологияләр (2005 тән) кафедралары проф. Хезмәтләре цифрлы схемаларга кертелгән тикшерү системаларына карый. С. кайбер классик төркемнәргә караган матрица элементлары өчен асимптотик формулалар һәм бер үк төрле бүленгән беренчел бәйсез хаталы сигнатур анализаторның оптималь структурасын таба. Программалаштырыла торган логик матрицаларда киң таралган хаталарның тулы классын табарга сәләтле тест сигналлары генераторының структурасын тәкъдим итә.

Х е з м.: Обнаружение ошибочных последовательностей нелинейным сигнатурным анализатором // Автоматика и телемеханика. 1991. № 7; Исчерпывающее тестирование программируемых логических матриц // Автоматика и телемеханика. 1993. № 3; Методы компактного тестирования цифровых схем. К., 1993.

**СТО́ЛОВ** Лев Израилевич (20.12.1905, Кишинёв ш. — 15.8.1995, Казан), электротехника өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1965), проф. (1966), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1945). 1928 елда Дон политехник ин-тын (Новочеркасск ш.) тәмамлаганнан соң, Харьков электромеханика з-дында эшли. 1931–45 тә Казан «Центроэлектромонтаж» идарәсендә. 1939 дан Казан авиация ин-тында, электротехника һәм электр

машиналары каф. мөдире (1939–77), проф. (1978 дән). Электр машиналары һәм түбән егәрлекле электр күчергече фәнни юнәлешенә нигез салучы. С. асинхрон микромашиналар теориясен, даими магнитлы моменталь двигательләр теориясен; төрле типтагы моменталь двигательләрнең конструкцияләрен һәм проектлау алымнарын; даими һәм алмаш токтагы микроэлектркүчергечләр теориясен эшли. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Моментные двигатели с постоянными магнитами. М., 1977 (автордаш); Авиационные моментные двигатели. М., 1979 (автордаш); Моментные двигатели постоянного тока. М., 1989 (автордаш).

**СТОЛЫ́ПИН** Пётр Аркадьевич (5.4.1862, Дрезден ш., Германия — 5.9.1911, Киев), дәүләт эшлеклесе, яшерен советник (1908). Дворяннар катлавыннан. Петербург ун-тын тәмамлый (1884). 1884 елдан Эчке эшләр министрлыгы ведомстволарында. 1889–99 да өяз, 1899–1902 дә губерна дворяннары җитәкчесе. 1902–09 да Гродно, 1903–06 да Саратов шәһәрләре губернаторы. 1906 дан МС рәисе һәм эчке эшләр министры. Бер үк вакытта, 1907 дән, Дәүләт Советы әгъзасы. 1905–07 еллар Рев-циясен бастыру б-н җитәкчелек итә. Илдә дәүләт ин-тларына булышлык итүгә, Россиянең эчке куәтен һәм халыкара аренада абруен көчәйтүгә юнәлтелгән масштаблы үзгәртеп корулар уздыруны оештыра һәм җитәкли (к. *Столыпинның аграр реформасы*). 1899 ның августында һәм 1910 ның сентябрендә төбәкнең социаль-икътисади хәле б-н танышу максатыннан Казанда һәм Казан губернасында була; төбәк үзенчәлекләре б-н кызыксына, губерна хакимиятләренә дәүләт реформаларын тормышка ашыруда булышлык күрсәтә. Ул төзегән «Себергә һәм Идел буена сәфәр» («Поездка в Сибирь и Поволжье», СПб., 1911) аналитик язма аның соңгы инспекциясе нәтиҗәсе булып тора. Изге Александр Невский ордены б-н бүләкләнә. Эсер Д.Г.Богров кулыннан үлем ярасына дучар ителә.

Х е з м.: Нам нужна Великая Россия... Полное собр. речей в Гос. Думе и Гос. Совете. 1906–1911. М., 1991; Переписка. М., 2004.

*Әд.:* С т о л ы п и н А.П. П.А.Столыпин. 1862–1911. Париж, 1927; Ф ё д о р о в Б.Г. Пётр Столыпин: «Я верю в Россию»: Биография: В 2 т. СПб., 2002; Р ы б а с С.Ю. Столыпин. М., 2003; Д о л г о в Е.Б. «Хозяева, выселившиеся на отруба, а затем их наследники станут богаче, образованнее, счастливее»: Из истории аграрной реформы П.А.Столыпина // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2009. № 1.

*Е.Б.Долгов.*

**СТОЛЫ́ПИННЫҢ АГРА́Р РЕФО́РМАСЫ**, 1906–17 елларда Россиядә уздырылган крәстиян җир иманалары реформасы. Реформаның инициаторы, 1906–11 дә МС рәисе П.А.*Столыпин* исеме б-н бәйле. Николай II нең «Крәстиян җир биләүчелеге һәм җирдән файдалану турында»гы 1906 ел 9 ноябрь Фәрманы нигезендә уздырыла, фәрман тарафыннан крәстияннәргә авыл җәмәгатеннән чыгарга, ә җәмәгать җирен шәхси милек итеп *хуторлар* һәм *отрублар* формасында беркетергә рөхсәт бирелә. Соңрак фәрман «Крәстиян җир биләүчелеге хакында кайбер карарларны үзгәртү һәм тулыландыру турында»гы 1909 ел 14 июнь һәм «Җир төзүчелек турында»гы 1911 ел 29 май законнары б-н тулылана. Алар крәстияннәрнең авыл җәмәгатеннән чыгу һәм аларның ялгыз хуҗалык оештыру (мәс., 24 ел буе җирне яңадан бүлү башкарылмаган крәстиян хуҗалыгы шәхси җир милкенә тиңләшә) тәртипләрен күпкә гадиләштерә. Хөкүмәт 1895 тә алпавытларның утарларын сатып алу хокукына ирешкән, аларны биләмәләргә бүлеп, крәстияннәргә яңадан саткан С.а.р.н гамәлгә ашыруда зур рольне *Крәстияннәр җир банкының Казан бүлеге*нә бирә. «Имана җирен залогка салу хокукы турында»гы 1906 ел 15 ноябрь Фәрманы нәтиҗәсендә, банкка залогка крәстияннәрнең имана җирен алып, аларга акчалата ссуда бирү хокукы бирелә. Бу ссудалар имана җирләре өчен түләүгә, башка чыгымнарны каплауга, җирдән файдалану формаларын яхшыртуга — аерым посёлоклар, хуторлар, отрублар төзелешенә һ.б.га тотыла. 1906 да С.а.р.н тормышка ашыру өчен урыннарда губерна (губернатор җитәкчелегендә) һәм өяз (өяз дворяннары башлыгы җитәкчелегендә) җир төзү комиссияләре оеша, алар адм.-мәхкәмә учреждениеләренә тиңләштерелә. Хөкүмәт әлеге чаралар б-н беррәттән җирсез һәм аз җирле крәстияннәрне илнең көнчыгыш төбәкләренә — Уралга, Көнчыгыш Себергә һәм кыргыз далаларына күчерү буенча актив сәясәт алып бара. Күчерү сәясәтенең максаты чирәм һәм яткын җирләрне үзләштерү, социаль киеренкелекне киметү, Россиянең Европа өлеше авыл җирләрендәге крәстияннәрнең аз җирлелеген бетерүдән гыйбарәт була. «Күчерү өлеше буенча законлаштыруны гамәлдән чыгару һәм үзгәртү турында»гы 1906 ел 10 март Фәрманы ташламалы шартларда теләгән кешеләргә күченү һәм урнашу өчен ссуда алып күчүне күздә тота.

Казан губернасында С.а.р. икътисадның аграр секторын үзгәртү гомумдәүләт программасы юнәлешендә алып барыла. Төбәктә реформа уздыру б-н Казан губернаторы җитәкчелек итә. 1906–07 дә 1 губерна һәм 10 өяз җир төзүчелек комиссиясе (Казан, Козьмодемьянск, Лаеш, Мамадыш, Зөя, Спас, Тәтеш, Цивильск, Чабаксар, Чистайда) оеша, алар земство һәм авыл җәмәгате б-н крәстиян имана җирләре төзелешен гамәлгә ашыралар, хуторлар һәм отрублар оештыралар. С.а.р. чорында крәстияннәрдән килгән җирдән файдалану шартларын яхшырту һәм булышлык итү турындагы үтенеч язулары 2 төп категориягә бүленә: җирдән файдалануда булган җитешсезлекләрне имана җирен хуторларга һәм отрубларга бүлү аша бетерү турындагы мөрәҗәгатьләр һәм имана җирләрен бер урынга туплау (аерым җир төзүчелек) турындагы үтенечләр. Крәстиян мөрәҗәгатьләре арасында кечкенә басулы, аралык басулы, күп басулы һәм ерак җирләрне пүчинкә, хутор һәм берничә авылдан торган яки күп хуҗалыгы (күмәк җир төзүчелек) булган җәмәгатьле ерак җирләр хисабына бетерү турындагы үтенечләр дә очрый.

1907–09 да Казан губернасында 17821 йорт хуҗасы имана җирен шәхси милек итеп рәсмиләштерә (гомуми саны 39844 ир-ат булган гаиләләр). 1907–15 тә Казан губернасында 592037 дис. а.х. файдалана торган җирләр яки имана җиренең гомуми мәйданының 17,5% ка якыны милекләштерелә. Губернада җир төзүчелекнең барлык формалары арасында күмәк җир төзүчелек үсеш ала, ул 476500 дис. яки бүленгән җирнең 81% ын тәшкил итә. 115000 дис.дән артыграк (19%) җир аерым биләмәгә бүлеп бирелә, бу төр Зөя һәм Чистай өязләрендә киң таралыш ала. Әлеге елларда аерым хуҗалыклы җир сыйфатында 13400 утар аерылып чыга, әмма аларның 984е генә (7,23%) үзләренә бүлеп бирелгән җиргә күчә һәм хутор хуҗалыгы булдыра. 1915 тә хуторлы кешеләргә 9000 дис., отруб хуҗалыкларына — 83000 дис. җир туры килә. Отруб хуҗалыгы бигрәк тә Чистай (губернадагы гомуми отрублар санының 26,6% ы), Тәтеш (17,4%), Спас (11,3%) һәм Лаеш (10,8%) өязләрендә киң тарала.

С.а.р. башыннан ук Җир банкының Казан бүлеге эшчәнлеге активлаштырыла. 1906 ел 27 август Фәрманы б-н Крәстияннәр банкына алга таба крәстияннәргә сату өчен удел һәм казна җирләренең бер өлеше бирелә. 1906–15 тә әлеге банк фондына күчкән җирләр мәйданының гомуми күләме — 85169 дис. (шулардан удел җирләреннән — 5632 дис., салымнарны даими түләмәүчеләрдән — 5346 дис., шәхси хуҗалардан — 74191 дис. җир алына). Банк бүлеге җир төзүчелек комиссияләре б-н бергә крәстияннәргә хутор һәм отрублар булдыруда ярдәм күрсәтә, ш.у. бурычка алучыларга (җир сатып алганнарга) ширкәтлек идарәсеннән аерым хуҗалыкка күчәргә булышлык итә. Банк булышлыгы б-н крәстияннәргә 3738200 дис. (барлык запасның 60,4%ы) җир сатыла.

Крәстияннәрне илнең көнчыгыш төбәкләренә күчерү сәясәтен гамәлгә ашыру максатыннан, яңа урындагы җирләр һәм яшәү шартлары б-н алдан барып танышу өчен, юллап йөрүчеләр төркемнәре булдырыла; күченүчеләр өчен аңлатмалы төрле брошюралар һәм кәгазьләр таратыла (ш.и. татар телендә дә), күченүчеләрне җибәрүнең чиратлары булдырыла һ.б. Әмма Казан губернасында күчерү сәясәте популярлык казанмый. 1905–14 тә Урал артына барлыгы 38620 кеше генә китә, аларның 6000 нән артыгы яңа шартларга җайлаша алмый һәм, үз җирләренә кайтып, батраклар санын тулыландыра.

С.а.р. чараларын гамәлгә ашырган елларда җирдән файдалануның яңа агротехник алымнары үзләштерелә, күп басулы чәчү әйләнеше мәйданнары арта. 1912–15 тә земство органнарының агрономия хезмәтләре тарафыннан Лаеш һәм Спас өязләрендә тәҗрибә басулары булдырыла, ул басуларда а.х. үсемлекләренең җирне эшкәртүнең төрле алымнарына, чәчү вакытына, органик һәм минераль ашламалар кертүгә реакцияләре тикшерелә һ.б. тәҗрибәләр алып барыла. Казан губернасының крәстиян халкы арасында агротехник

белемнәр таралыш ала: лекцияләр укыла, аңгәмәләр алып барыла, курслар уздырыла һ.б.

Губерна крәстияннәре хөкүмәтнең социаль-икътисади сәясәтен бертөрле генә кабул итми, аларның күпчелеге җир биләүчелекнең традицион җәмәгать формасын саклавын дәвам итә, җир төзүчелектәге теләсә нинди яңалыкка сак карый. Җәмәгатьтәгеләр еш кына аерылып чыккан крәстияннәр һәм хөкүмәт вәкилләре б-н низагка керә: авыл җыеннары җәмәгатьтән чыгу турында карар кабул итүдән баш тарталар, җир төзүчелек эшләре вакытында дәүләт җир үлчәүчеләренә һәм техникларга ярдәм итәргә теләмиләр, крәстияннәр ызан билгеләрен юкка чыгаралар, хөкүмәт вәкилләренә һөҗүм итәләр (1912 нең маенда Казан губернасындагы авылларда җир төзүчелеккә каршы 77 крәстиян чыгышы теркәлә).

Беренче бөтендөнья сугышы башыннан реформалау темпы кискен түбәнәя. 1917 нең Февр. рев-циясеннән соң хуторларны, отрубларны юк итү, бүленеп чыккан кешеләрнең җирләрен авыл җәмәгате карамагына кайтару башлана. Алга таба С.а.р. чараларын гамәлгә ашыру Вакытлы хөкүмәтнең 1917 ел 28 июнь карары б-н туктатыла.

Чыг.: Обзоры Казанской губернии за 1904–1914 гг. К., 1905–15; Крестьянское землевладение в Казанской губернии: В 13 вып. / Оценочно-стат. бюро Казан. губернского земства. К., 1907–09; Итоги переселенческого движения за время с 1910 по 1914 гг.: В 2 т. П., 1910–16; Укрепление наделов в личную собственность в Казанской губернии (Указ 9 ноября 1906 г. и закон 14 июня 1910 г.) / Оценочно-стат. бюро Казан. губернского земства. К., 1911.

*Әд.:* Андреевский И.Д. Деятельность Крестьянского поземельного банка по Казанской губернии (1906–1915 гг.) // Тр. Об-ва изучения Татарстана. 1930. Т. 1; Скляров Л.Ф. Переселение и землеустройство в Сибири в годы столыпинской аграрной реформы. Л., 1962; Кабытов П.С. Аграрные отношения в Поволжье в период империализма (1900–1917). Саратов, 1982; Люкшин Д.И. Крестьяне — общинники Казанской губернии в социально-политических сдвигах начала XX века. К., 2006.

*Р.Р.Батыршин.*

**СТОЛЯРО́В** Николай Георгиевич (22.5.1922, Казан — 23.2.1993, Мәскәү), ике тапкыр Сов. Союзы Герое (1.7.1944 һәм 27.6.1945), гв. полковнигы. Казан аэроклубын (1940), Свердловск хәрби-авиация мәктәбен (1941), Полтава штурманнар югары офицерлар мәктәбен (1946), Хәрби-һава академиясен (Мәскәү, 1954) тәмамлый. 1942 елның декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 292 нче авиация штурм дивизиясенең 667 нче авиация штурм полкында (5 нче һава армиясенең 1 нче авиация штурм корпусы) звено командиры; 3 нче гв. авиация штурм дивизиясенең 141 нче гв. авиация штурм полкында (2 нче һава армиясенең 1 нче гв. авиация штурм корпусы) авиаэскадрилья командиры урынбасары һәм командиры, штурман. Калинин, Воронеж, Дала, 2 нче Украина һәм 1 нче Украина фронтлары составында сугышларда катнаша. 180 нән артык сугышчан очыш ясый. Шәхсән дошманның 8 самолётын бәреп төшерә. Курск сугышы (1943), Днепр елгасын кичү (1943), Полтава, Кременчуг һәм Кировоград шәһәрләрен азат итү (1943–44) вакытындагы 96 очыш, дошман авиациясе б-н һава сугышларында күрсәткән батырлыгы өчен С.ка Сов. Союзы Герое исеме бирелә. Корсунь-Шевченковский (1944), Львов-Сандомир (1944), Берлин (1945) һәм Прага (1945) һөҗүм операцияләре барышында сугышчан каһарманлык һәм фидакарьлек күрсәткәне өчен, кабат Сов. Союзы Герое исеменә лаек була. Сугыштан соң штурман һәм авиаполк командиры булып хезмәт итә. 1956 дан запаста, Мәскәүдә яши һәм эшли. Ленин ордены, Кызыл Байрак, Александр Невский, ике 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казанда бер урам С. исемен йөртә, Геройга бронза бюст куелган.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СТОЛЯРО́В Н.Г. БЮСТЫ́**, Казанда. Ике тапкыр Сов. Союзы Герое, очучы Н.Г.*Столяров* һәйкәле. 1950 елда Н.Г.Столяровның икенче «Алтын Йолдыз» медале б-н бүләкләнүе һәм бүләкләнүченең туган ягында бронза бюстын урнаштыру турында СССР ЮС Президиумы указы нигезендә Клара Цеткин урамындагы скверда куела.

Авторлары — скульп. В.И.Мухина (танылган «Эшче һәм колхозчы хатын-кыз» әсәрен иҗат итүче), арх. И.Г.Гайнетдинов. Совет монументаль скульптурасының реалистик традицияләрендә башкарылган бюст зур тәгәллек б-н Ватанны саклаучы образын бирә. Скульптура тантаналы күтәренкелеге, монументальлеге һәм тәэсирлелеге б-н аерылып тора. Горур күтәрелгән башы, җитди йөзе, ныклы, ачык карашы энергиясен, тәвәккәллеген һәм максатчанлыгын күрсәтеп тора. Шомартылган соры гранит постаментка бронза бюст кую турындагы указ тексты урнаштырылган.

*А.И.Новицкий.*

**СТОЛЯРО́ВА** Гүзәл Рафаил кызы (25.4.1956, Мамадыш ш.), этнограф, тарихчы, тарих фән. д-ры (2005), проф. (2009). Казан ун-тын (1978) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 2000–02 елларда этнография һәм археол. каф. мөдире. Хезмәтләре Урта Идел буе халыкларының этнографиясен, этносоциологиясен һәм этнодемографиясен өйрәнүгә карый. Европа этнографлары һәм фольклорчылары фәнни җәмгыяте әгъзасы. РФнең мактаулы югары белем бирү хезмәткәре (2011).

Хезм.: Этнодемографические процессы в Казанском Поволжье. К., 1991 (автордаш); Феномен межэтнического взаимодействия: Опыт постсоветского Татарстана. К., 2004; Этнография народов Волго-Уралья. К., 2007 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3; Наши юбиляры // Уч. зап. Казан. ун-та. Сер. Гуманитар. науки. 2006. Т. 148, кн. 4.

**СТОМАТОЛО́ГИЯ** (грек. stóma, и.к. stómatos — авыз һәм *...логия*), клиник мед. өлкәсе, авыз куышлыгы, теш казналыгы — бит тирәсе әгъзалары авыруларының барлыкка килүен, аларны ачыклап диагноз кую һәм булдырмау чараларын, авыруларны һәм



Н.Г.Столяров.

патологик тайпылышларны дәвалау ысулларын, ш.у. стоматологик материалларны һәм аларны куллану алымнарын өйрәнә. Берничә төргә: терапевтик (теш, пародонт, авыз куышлыгының лайлалы тышчасы авыртулары очракларында диагноз кую, авыруларны кисәтү һәм дәвалау), хирургик (теш алу; казналык-бит тирәсендәге ялкынсынулар, бит һәм казналыктагы тумыштан булган яки барлыкка килгән дефектлар, яман яки яман булмаган шешләргә операция ясау), ортопедик (теш рәтендәге дефектларны өлешчә яки тулысынча, ш.и. имплантантлар кулланып алыштыру) С.гә, балалар С.сенә (стоматологик авыруларны үсеш чоры үзенчәлекләрен исәпкә алып дәвалау) һәм ортодонтиягә (аерым теш, тешләр рәте һәм казналык аномалияләренә диагноз кую, авыруны кисәтү һәм дәвалау) бүленә.

Авыз куышлыгы авырулары беренче тапкыр Сушрута (Борынгы Һиндстан), Гиппократ (Борынгы Греция), Гален, Цельс (Борынгы Рим) һ.б. табибләрнең хезмәтләрендә тасвирлана. Француз табибе Ги де Шолиак теш алу өчен инструмент тәкъдим итә (14 йөз), италияле медик Дж.Аркале тешләрне алтын, кургаш һәм аккургаш фольга б-н пломбалау турында телгә ала, А.Паре теш алу техникасын һәм тешләрне реплантацияләү операциясен тасвирлый (16 йөз, Италия). С.гә фәнни дисциплина буларак нигез салучы итеп «Тешләрне дәвалау һәм теш хирургиясе буенча кулланма» («Руководство по хирургии и лечению зубов», 1728) авторы, француз хирургы П.Фошар исәпләнә. Төп стоматологик авыруларның этиологиясе, патогенезы һәм терапиясе 19 йөз ахырында — 20 йөз башында өйрәнелә. Русьта 16 йөздә һөнәрчеләр арасында теш йолкучылар телгә алына. Россиядә теш дәвалау б-н шөгыльләнү хокукын иң беренче булып 1710 елда француз Ф.Дюбрель ала, 1810 да махсус закон б-н теш табибе вазифасы кертелә, 1829 да хатын-кызларга теш дәвалау б-н шөгыльләнү хокукы бирелә. 1881 дә С.-Петербургта Ф.И.Важинский җитәкчелегендәге «теш табиблеге сәнгатен» өйрәнү мәктәбе ачыла, 1883 тә «Россия беренче дантистлар җәмгыяте» һәм «Дантистлар һәм теш дәвалау б-н шөгыльләнүче табибләр җәмгыяте» оеша, соңрак андый җәмгыятьләр Мәскәүдә (1891) һәм башка шәһәрләрдә дә барлыкка килә. 20 йөздә С. үсешенә А.К.Лимберг һәм М.М.Чемоданов зур өлеш кертә. 1917 дән соң югары уку йортларының мед. ф-тлары каршында С. кафедралары һәм белем күтәрү курслары оештырыла. 1922 дә Мәскәүдә Теш



Г.С.Сторожев.

дәвалау ин-ты (хәзер Мәскәү мед.-стомат. ун-ты) ачыла, 1935 кә илдә 11 С. ин-ты исәпләнә. 1975 тә СССРда 2 С. ин-ты һәм мед. ин-тларында 33 С. ф-ты була. 1962 дә Мәскәүдә СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Үзәк С. фәнни-тикшеренү ин-ты ачыла. 1956 да Бөтенсоюз стоматологлар җәмгыяте оеша (1968 дә Халыкара стоматологлар җәмгыятенә керә).

Казанда беренче теш дәвалау мәктәбе 1899 да ачыла (35 кеше кабул ителә), А.О.Рясенцев тырышлыгы б-н 1908 дә икенче мәктәп барлыкка килә. 1918 дә РСФСР ХКС карары нигезендә Мәскәү, Петроград, Саратов һәм Казандагы теш дәвалау мәктәпләре ун-тның мед. ф-тларындагы одонтология бүлекләренең укыту-ярдәмче учреждениеләре итеп үзгәртелә. 1919 да Казан ун-тының мед. ф-тында «Теш авырулары патологиясе һәм терапиясе; тешләрне консерватив дәвалау клиникасы» («Патология и терапия зубных болезней с клиникой консервативного зубоврачевания») курсы укыла (П.А.Глушков). 1920 дә мед. ф-тында, Россиядә беренчеләрдән булып, одонтология кафедрасы ачыла (оештыручысы — П.А.Глушков; 1930 дан Казан мед. ин-ты составында). Казанда югары стоматологик белем бирү шул кафедрадан башлана. Квалификацияле табиб-стоматологлар әзерләү максатыннан 1936 да СССР ХКСның махсус карары нигезендә С. ин-тлары оештырыла (ш.и. Казанда да; беренче директоры — И.М.Утробин, 1938 дән — Г.Ф.Тихонов); 1950 дә ин-т Караганда шәһәренә күчерелә. 1954 тә Казан мед. ин-тында С. ф-ты ачыла, 1958 дә ф-тта ортопедик С. (мөдирләре — И.М.Оксман, Л.М.Демнер, М.З.*Миргазизов*, 1996 дан — И.И.Гыйниятуллин), хирургик С. (мөдирләре — Е.А.*Домрачева*, Л.А.*Кольцова*, 1998 дән — Т.Т.*Фәизов*), терапевтик С. (мөдирләре — С.И.Вайс, Г.Д.*Овруцкий*, 2007 дән — Г.Т.Салиева), балалар С.се (1994 тән мөдире — Р.З.Уразова) кафедралары оештырыла. 1934 тә Казан ГИДУВында респ-ка стоматологларының белемнәрен күтәрү максатыннан С. кафедрасы булдырыла (мөдирләре — И.М.Утробин, С.И.Вайс, И.М.Оксман, 1970 тән — Ф.Г.Гасыймов), 1970 тә терапевтик С. (мөдирләре — Ф.Г.Гасыймов, 1991 дән — В.Ю.*Хитров*), ортопедик С. (мөдирләре — Г.Г.*Насыйбуллин*, 2008 дән — Н.И.Шәймиева), хирургик С. (мөдирләре — Ф.С.Хәмитов, И.Г.Ямашев, 2008 дән — О.В.Нестеров) кафедралары барлыкка килә.

Казан галим-стоматологлары тарафыннан авыз куышлыгының лайлалы тышчасы иннервациясенең морфологик аспектлары һәм теш-казналык протезлары куюның катлаулы очраклары (И.М.Оксман), битнең яралы җәрәхәтләре очрагында ашыгыч пластика (Е.А.Домрачева), селәгәй бизләренең анафилактик реакциясе (С.И.Вайс), теш кариесын кисәтүдә фторның әһәмияте (Г.Д.Овруцкий) өйрәнелә; ортодонтны (А.А.Погодина, Л.М.Демнер), чигә-казналык буыны патологиясен, ортопедик тайпылышларны (Г.Г.Насыйбуллин) дәвалауда, форма хәтерен саклаучы имплантантлар кулланып протезлар эшләүдә (М.З.Миргазизов) яңа ысуллар гамәлгә кертелә. Казан мед. ин-тының (1994 тән — мед. ун-ты) С. ф-тында Чиләбе, Төмән, Горький, Саратов һәм Ульянов өлкәләре, Чуаш, Удмурт, Чечен, Мари, Мордва, Ингуш респ-калары өчен табиб-стоматологлар әзерләнә; Һиндстан, Камерун, Ливан, Марокко, Сүрия, Төркия һ.б. илләрдән килеп укыган 40 кеше табиб-стоматолог белгечлеге алып чыга. 1956 да — Респ-ка стоматологлар җәмгыяте (рәисләре — И.М.Оксман, Г.Д.Овруцкий, Г.Г.Насыйбуллин), 1994 тән ТР С. ассоциациясе оеша (президентлары — М.З.Миргазизов, Н.И.Шәймиева). ТРның стоматологик юнәлештәге дәвалау-профилактика учреждениеләрендә 2 меңнән артык табиб-стоматолог эшли. 2013 елга ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында бюджеттан финансланучы һәм хуҗалык исәбендәге 12 С. поликлиникасы, ш.и. 5 балалар С. поликлиникасы исәпләнә. С. бүлекләре (кабинетлары) булган дәвалау-профилактика оешмалары — 63; мөстәкыйль һәм дәвалау-профилактика оешмалары составында эшләүче теш протезлары бүлекләре (кабинетлары) — 49.

*Әд.:* Казанский ГИДУВ им. В.И.Ленина (1920–1990). К., 1990; Хитров В.Ю. 60 лет последипломной подготовке стоматологических кадров в Казанской государственной медицинской академии: Итоги и перспективы. К., 1995; Миргазизов М.З. Казанская школа стоматологов и её роль в развитии отечественной стоматологии // Казан. вестн. стоматологии. 1996. № 7; Стоматологическому факультету Казанского медицинского университета 50 лет. К., 2004.

*В.Ю.Хитров, И.М.Андреев.*

**СТОПА́НИ** Александр Митрофанович (9.10.1871, Иркутск губ., Иркутск округы Усолье а. — 23.10.1932, Мәскәү), дәүләт һәм партия эшлеклесе. Дворяннар катлавыннан. Казанда Беренче ир балалар гимназиясен (1892), Демидов юридик лицеен (Ярославль ш., 1896) тәмамлый. 1892–94 елларда Казан ун-ты студенты. 1889 дан гимназиядә «үзлектән үсеш» түгәрәген җитәкли, 1892 дә Казанда с.-д. түгәрәген оештыра һәм аны 1894 кә кадәр җитәкли. Казан губернасы эшчеләре, укучы яшьләре, хәрбиләре арасында марксистик идеяләрне пропагандалый. 1896–1900 дә Ярославль губернасының земство идарәсе статистигы. Псков, Баку, Кострома шәһәрләрендә революцион хәрәкәттә катнаша. Төньяк Кавказда, Пермьдә, Мәскәүдә партия һәм дәүләт эшендә. 1922 дән РСФСРның Хезмәт халык комис-тында, РСФСР Югары мәхкәмәсе әгъзасы. 1924–29 да хезмәт урыныңдагы бәхәсләр буенча РСФСР прокуроры. 1930 дан Бөтенсоюз карт большевиклар җәмгыяте рәисе урынбасары. Революцион хәрәкәт тарихы, икътисади статистика буенча хезмәтләр авторы.

Хезм.: Освещение в селениях Полтавской губернии. Баку, 1904; Нефтепромышленный рабочий и его бюджет. Баку, 1916; Очерки новой деревни и партработы в ней: По материалам о Волоколамском уезде. М.–Л., 1926.

*Әд.:* Элерт А. Стопани Александр Митрофанович // Борцы за счастье народное. К., 1967; Летопись борьбы и свершений: Хроника партийной организации Татарии. 1883–1985. К., 1985. Кн. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**СТОПА́НИНЫҢ СОЦИА́Л-ДЕМОКРАТЛА́Р ТӨРКЕМЕ́**, Казан студентлары б-н эшче яшьләрнең яшерен сәяси оешмасы. 1892 елның көзендә А.М.*Стопани* оештыра. Түгәрәк составына Н.Бауман, М.Березин, А.Бурцев, В.Исаенко, Я.Кубли, П.Мургин, А. һәм И. Петровлар, В.Сущинский, Е.Табейкин, В.Трапезников, С.Щербаков һ.б. (барлыгы 20 гә якын кеше) керә. Яшьләр, эшчеләр, һәм хәрбиләр арасында марксизм идеяләрен аңлату һәм тарату б-н шөгыльләнә. 1892 дә эшчеләрнең үзара ярдәмләшү кассасын оештыра, прокламацияләр чыгара. 1894 тә А.М.Стопани Казаннан киткәч, түгәрәк таркала.

*Е.Б.Долгов.*

**СТО́РОЖЕВ** Георгий Степанович (19.4.1918, Буа ш. — 31.10.1994, шунда ук), тракторчы-машинист, Соц. Хезмәт Герое (1948). 1936 елдан Буа районында эшли: комбайнчы, МТСта трактор бригадасы бригадиры (1947), «Кызыл Йолдыз» к-зында (1958 дән), электрик-аккумуляторщик, а.х.н җитештерү-техник тәэмин итү буенча район ЖБдә электр җиһазларын ремонтлау буенча слесарь (1964 тән), «Росводремстрой» ПМКсында тимерче (1978–81). С. җитәкчелегендә бригада трактор һәм комбайннарның сезонлы эшләп чыгару күләмен арттыруга, туфрак эшкәртү сыйфатын яхшыртуга, а.х. культураларының уңышын 2,5 тапкыр арттыруга ирешә. Герой исеме уҗым арышыннан югары уңыш алганы өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә. Буадагы бер урамга С. исеме бирелә (1988).

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**СТОЯ́НОВ** Олег Владиславович (13.1.1960, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1997), проф. (1998). 1982 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, сәнәгать куркынычсызлыгы (1998–2005), пластик массалар технологиясе (2007 дән) кафедралары мөдире, пластмасса һәм композитлар технологиясе, аларны эшкәртү һәм сертификацияләү ф-ты деканы (2006 дан). Хезмәтләре композицион полимер материалларга һәм капламнарга карый. С. капламнар ясау процессында полиэтиленны химик тегү закончалыкларын билгели. Саклагыч капламнар ясау өчен полиолефиннарны полифунк-

**Татарстан Республикасы территориясендә геологик катламнарның стратиграфик (геохронологик) шкаласы**

| Эонотема (эон) | Эратема (эра) | Система (период) | Бүлек (эпоха) Дүртенчел системада – бүленеш (фаза) | Ярус (гасыр) Дүртенчел системада – буын (чор) | Башы (млн. ел) | Файдалы казылмалар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| ФАНЕРОЗОЙ | КАЙНОЗОЙ | Дүртенчел | Голоцен | | 0,0118 | |
| | | | Неоплейстоцен | Югары | 1,806 | |
| | | | | Урта | | |
| | | | | Түбән | | |
| | | | Эоплейстоцен | Югары | | |
| | | | | Түбән | | |
| | | Неоген | Плиоцен | Акчагыл | 23,03 | |
| | | | | Киммерий | | |
| | | | Миоцен | Понт | | |
| | | | | | 65,5 ± 0,3 | |
| | МЕЗОЗОЙ | Акбур | Югары (соңгы) | Кампан | 88,6 | |
| | | | | Сантон | | |
| | | | | Коньяк | | |
| | | | Түбән (иртә) | Альб | 145,5 ± 4,0 | МБФК |
| | | | | Апт | | |
| | | | | Баррем | | |
| | | | | Готериф | | |
| | | Юра | Югары (соңгы) | Идел (төбәк ярусы) | 167,7 ± 3,5 | С |
| | | | | Киммеридж | | |
| | | | Урта | Келловей | | |
| | | | | Бат | | |
| | | | | | 251 | |
| | ПАЛЕОЗОЙ | Пермь | Татар | Вятка | 260,4 ± 0,7 | |
| | | | | Северодвинск | | |
| | | | Биармия | Уржум | 299 ± 0,8 | Cu Ag |
| | | | | Казан | | |
| | | | Урал буе | Уфа | | |
| | | | | Көнгер | | |
| | | | | Арты | | Б |
| | | | | Сакмар | | |
| | | | | Ассель | | |
| | | Ташкүмер | Югары (соңгы) | Гжель | 359,2 ± 2,5 | |
| | | | | Касыйм | | |
| | | | Урта | Мәскәү | | |
| | | | | Башкорт | | К |
| | | | Түбән (иртә) | Серпухов | | |
| | | | | Визе | | |
| | | | | Турне | | |
| | | Девон | Югары (соңгы) | Фамен | 397,5 ± 2,7 | Н |
| | | | | Фран | | |
| | | | Урта | Живе | | |
| | | | | Эйфель | | |
| | | | | | 542 ± 1,0 | |
| КЕМБРИЙГАЧА КАТЛАМНАР ШКАЛАСЫ | | | | (төбәк горизонт, серия) | | |
| ЮГАРЫ ПРОТЕРОЗОЙ | | Венд | Югары | Бишбүләк | 650 ± 20 | |
| | | | Түбән | | | |
| | РИФЕЙ | | | | 850 ± 30 | |
| | ЮГАРЫ | | | Соловьёвка (Чишмәле) | 1100 ± 50 | |
| | | | | | 1350 ± 50 | |
| | ТҮБӘН | | | Кырпы (Кидаш) | 1600 ± 50 | |
| | | | | Карач | | |
| ТҮБӘН ПРОТЕРОЗОЙ | | | | | 2500 ± 50 | |
| АРХЕЙ | | | | | (3109 ± 97)* 4500 дән артык | |

Россиянең Гомум стратиграфик (геохронологик) шкаласына (2006) һәм "The concise Geologic Time Scale"га (2008) ярашлы рәвештә төзелә.
Файдалы казылмалар: Н – нефть, К – күмер, Б – битум, Cu – бакыр, Ag – көмеш, МБФК – металл булмаган файдалы казылмалар, С – җир асты сулары.
* ТР территориясендәге аеруча борынгы токымнар.

циональ тәэсир итүче матдәләр б-н модификацияләүнең физик-химик нигезләрен эшли. Саклагыч капламнар өчен порошоксыман полимер композицияләр, ш.у. торба үткәргечләрне коррозиядән изоляцияләү өчен адгезион материаллар таба һәм гамәлгә кертә. Уйлап табуга 30 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2007). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Кинетика сорбции и структурные превращения в системе химически сшитый полиэтилен — растворитель // Высокомолекулярные соединения. Сер. А. 1985. Т. 27, № 9 (автордаш); Роль кислотно-основных взаимодействий в формировании адгезионных соединений полимеров с металлами // Клеи. Герметики. Технологии. 2005. № 10 (автордаш); Studies on the Surface Properties and the Adhesion to Metal of Polyethylene Coatings Modified with Primary Aromatic Amines // Journal of Applied Polymer Science. 2001. V.79 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**СТРАТИГРА́ФИЯ** (лат. stratum — катлам, түшәү һәм ...*графия*), 1) геол. бүлеге, тау токымнары формалашу эзлеклелеген һәм аларның беренчел фәзаи урнашуын өйрәнә. Тарихи геол., *палеонтология, геохронология, литология*, утырма файдалы казылмалар геологиясе б-н тыгыз бәйләнештә. Бу фәннәрнең алымнарын, ш.у. климат-стратиграфик, геохимик һәм геофизик алымнар куллана. С.нең төп бурычы — тау токымнарының стратиграфик бүленеше эзлеклелеген һәм үзара бәйләлеген күрсәткән, җир кабыгының тарихи үсеше этапларын чагылдырган стратиграфик шкала төзү. Гомуми һәм төбәк С.ләре аерып йөртелә. С.нең фән буларак үсеп китүе 17 йөз башында, Дания галиме Н.Стено тау токымнарының эзлекле рәвештә катламлану законын ачканнан соң башлана. 19 йөздә төп геол. системалар бүленә, аларның эзлеклелеге билгеләнә, гомуми җыелма стратиграфия шкаласы төзелә, 19 йөз ахырында — 20 йөз башында гомуми шкала интервалларын детальләштерү үткәрелә, руда һәм нефть интерваллары аерып күрсәтелә. Татарстан терр-ясенең геол. төзелешен өйрәнә башлау 18 йөз уртасына туры килә, һәм ул П.С.*Паллас*, И.И.*Лепёхин* исемнәре б-н бәйле. Россиянең Көнчыгыш Европа өлешен геол. өйрәнү материаллары буенча Р.И.*Мурчисон* гомуми стратиграфик шкалага яңа Пермь системасын кертә (1841), Н.А.*Головкинский* — фациаль стратиграфик тикшеренү алымнарын (1868), М.Э.*Ноинский* ритмостратиграфия алымнарын (1920 еллар) эшлиләр. С.Н.*Никитин* — татар (1886), А.А.*Штукенберг* — Көнгер (1890), А.В.*Нечаев* Казан (1887) һәм Уфа (1915) ярусларын, М.Э.Ноинский Бәләбәй свитасын (1932), В.И.*Игнатьев* Бөгелмә горизонтын (1962) билгелиләр. 20 йөзнең 2 яртысында архей (Б.С.Ситдыйков), рифей һәм венд (Л.Ф.Солонцов, Е.М.*Аксёнов*), девон һәм карбон (И.А.Антропов, Б.В.*Буров*, Е.Д.*Войтович*, В.С.*Губарева*, Ф.С.Мальковский һ.б.), Пермь (В.А.*Чердынцев*, Е.И.*Тихвинская*, В.И.Игнатьев, Б.В.Буров һ.б.), кайнозой (Г.П.*Бутаков*, А.П.*Дедков*, Н.В.*Кирсанов*, О.Н.Малышева) төбәк стратиграфик схема-

лары җентекләп өйрәнелә. Стратиграф-палеонтологлар һәм палеоботаниклар организмнарның аерым төркемнәре буенча зона схемаларын булдыру б-н бер үк вакытта киселешләр бүлгәләнүен ачыклыйлар (Н.К.*Есаулова*, Т.А.Кузнецова, М.Г.*Солодухо*, В.В.*Силантьев*, Л.С.Тузова, В.Г.*Халымбаджа* һ.б.). Дөньякүләм стандартлар буларак югары Пермь киселешләрен палеоботаник нигезләү үткәрелә, Идел-Урал бассейнының югары Пермь стратотипларына комплекслы сыйфатлама бирелә (Н.К.Есаулова, И.Я.Жарков). Югары Пермьнең терек палеомагнит киселешләре тикшерелә, АКШ, Көнбатыш Европа, Кытай һәм дөньяның башка төбәкләрендәге утырмалар б-н корреляция үткәрелә (В.П.*Боронин*, Б.В.Буров, А.С.*Борисов*, Д.К.*Нургалиев*). Стратиграфик киселешнең рудалы, нефть-газлы интерваллары аерым күрсәтелә (У.Г.*Дистанов*, Е.И.Тихвинская, Р.Х.Мөслимов һ.б.). Татарстан терр-ясе С.сен нигезле тикшеренүләр «Татарстан геологиясе: Стратиграфия һәм тектоника» («Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника», М., 2003; ТР Дәүләт бүләге, 2005) монографиясендә тупланган. ТР терр-ясендә билгеләнгән төп стратиграфик бүлекчәләрнең чагылышы һәм утырмаларның абс. яше таблицада бирелгән. Татарстанда С. буенча тикшеренүләр Казан ун-тында, ЦНИИгеолнеруд, «Татнефть» АҖ һ.б. оешмаларда үткәрелә. 1998 елда Казанда «Идел буеның югары Пермь стратотиплары» дигән Халыкара симпозиум үтә. 2) *Археология* бүлеге, мәдәни катлауларның чиратлашу тәртибен, кеше эшчәнлеге калдыкларын (борынгы корылмалар һәм предметлар, төзелеш һәм хуҗалык чүп-чарлары, көл һ.б.) өйрәнә.

*Әд.:* Стратиграфический кодекс России. СПб., 2006. *Э.Х.Рәхмәтуллин.*

**СТРАТО́НОВ** Иринарх Аркадьевич (11.1.1881, Казан — 1945, Германия), тарихчы, рус тарихы магистры (1910). Дворяннар катлавыннан. Казан ун-тын тәмамлый (1906), шунда ук эшли: 1907–10 елларда проф. стипендиаты, 1914–17 дә приват-доцент, 1917–18 дә доцент, 1918–22 дә рус тарихы каф. профессоры. Бер үк вакытта, 1906–19 да, Казан югары хатын-кызлар курсларында, директор ярдәмчесе (1908–12, 1914–17), курслар директоры вазифаларын башкаручы (1911, 1918–19). 1919–22 дә ТАССР (1920 гә кадәр — Казан губ. буенча) Архив эшләре баш идарәсе уполномоченные. Җирле архивларны саклау һәм үзгәртеп кору, кулъязмаларны тикшерү комиссияләре б-н җитәкчелек итә. 1922 дә Казан ун-ты профессорлары забастовкасында катнаша, шул ук елның сентябрендә РСФСРдан Германиягә сөрелә. 1923–33 тә Рус фәнни ин-тында, 1933–38 дә Берлинда Кадакас рус эмигрантлары йортында идарәче булып эшли. 1939–42 дә Парижда яши. Икенче бөтендөнья сугышы елларында патриотик позиция били. 1938–39, 1942 дә фашистларга каршы пропаганда өчен гестапо тарафыннан кулга алына. Раненбург шәһәре янындагы концлагерьда һәлак була. Хезмәтләре Борынгы Русь кануннар мәҗмугасы тарихына, 16–17 йөзләр Рус дәүләтендәге катлау — вәкиллекле органнар тарихына карый. «Бөтенроссия патриарх чиркәве документлары» («Документы Всероссийской патриаршей церкви», Берлин, 1927), «Рус Чиркәве болгавырлыгы тарихыннан очерклар» («Очерки по истории русской церковной смуты», Берлин, 1927), «Рус чиркәве болгавырлыгы» («Русская церковная смута», Берлин, 1932), «Патриарх чиркәвенең хәзерге төзелеше барлыкка килү» («Происхождение современного устройства патриаршей церкви», Париж, 1933) һ.б. хезмәтләре Рус православие чиркәвенең Окт. рев-циясеннән соңгы торышын анализлауга багышлана. С. чит ил православие приходларын Мәскәү патриархлыгына буйсындыруны яклый. 1917–18 дә Рус православие чиркәвенең Поместный соборы депутаты.

Х е з м.: Заметки по истории земских соборов Московской Руси. К., 1905; К вопросу о составе и происхождении краткой редакции «Русской Правды». К., 1920.

*Әд.:* С у л т а н б е к о в Б.Ф., М а л ы ш е в а С.Ю. Трагические судьбы. К., 1996; С у х а р е в Ю.Н. Материалы по истории русского научного зарубежья. М., 2002. Кн. 1; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3. *Е.Б.Долгов.*

**СТРЕ́ЖНЕВ** Василий Александрович (27.3.1931, Чуаш АССРның Алатырь р-ны Кувакино а. — 16.5.2002, Казан), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1991), проф. (1993). 1954 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1957–2002 дә Казан техник ун-тында эшли, махсус математика каф. мөдире (1975–84), каф. профессоры (1992–2001). Хезмәтләре матем. модельләштерүгә, механикага, фәзадагы идарә системалары теориясенә карый. С. махсус төрдәге оптика-механик системаларның конструктив параметрларына вибрацион анализ ясау һәм оптималь кыйммәтләр сайлап алу методикасын эшли; хәрәкәтчән нигезләргә урнаштырыла торган аэрофотография системаларында оптик сурәтнең авышуын төзәтү һәм аны тотрыклы итү юлын тәкъдим итә; «Сатурн» стратосфера-кояш обсерваториясен әзерләгәндә кулланылган матем. модель төзи (станциянең 1966, 1967, 1970, 1973 еллардагы очышы нәтиҗәсендә Кояш фотосферасының активлыгы һәм нәзек структурасы хакында уникаль фәнни мәгълүмат алына). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Динамика стратосферной обсерватории // Управление в пространстве: Сб. науч. тр. 5 Междунар. симпозиума ИФАК по автоматич. управлению в пространстве. М., 1975. Т. 1 (автордаш); Задачи инвариантности и устойчивости в динамике стратосферных обсерваторий. Новосиб., 1983 (автордаш); О построении математических моделей и законов стабилизации оптического изображения в управляемых аэрофотографических системах на подвижных основаниях // Вестн. Казан. техн. ун-та. 1997. № 1.

**СТРЕКА́ЛОВ** Степан Степанович (1781 — 25.11.1856, Мәскәү), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, генерал-лейтенант (1830), сенатор (1841), хакыйкый яшерен советник (1844). Дворяннар катлавыннан. 1796 елдан хәрби хезмәттә. 1805–07 еллардагы рус-француз, 1812 елгы Ватан, 1828–29 еллардагы рус-төрек сугышларында, рус гаскәрләренең 1813–15 еллардагы чит илләргә яуларында, 1825 нең 14 декабрендә С.-Петербургтагы декабристлар фетнәсен бастыруда катнаша. Гражданнар б-н эшләү вәкаләтләре булган Тифлис (1828–31) һәм Казан (1831–41) хәрби губернаторы. Кырыс идарәче сыйфатларын кулланып, С. губерна хакимиятләре б-н җирле дворяннар арасындагы каршылыкны җайга сала һәм Казан төбәге б-н нәтиҗәле җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра. Аның чорында 8 нче «җан башыннан ревизия» — губерна халкын исәпкә алу уздырыла (1833–36), «Заволжский муравей» ж-лы (1832–34), «Казанские губернские ведомости» г-тасы (1838 дән) нәшер ителә башлый; Казанда Анатомия театры (1837), университет клиникалары (1840) биналары салына. С. мед. учреждениеләре эшчәнлеген яхшыртуга (аның әмере б-н халык арасында авыруларны булдырмау өчен чәчәк чиренә каршы көрәш буенча губерна һәм земство ком-тлары эшчәнлекләре яңартыла), губерна шәһәренең мәдәни һәм хуҗалык тормышы үсешенә (шәһәр театрының «император» статусын алуына ирешә, 1835 тә театр өчен яңа бина салырга әмер бирә, 1837 дә «мануфактура һәм табигый әсәрләр» күргәзмәсен оештыруга булышлык күрсәтә) зур өлеш кертә. С. стат., мануфактура, төрмәләр буенча губерна попечительләр ком-тларын оештыруга (1835), Казанда Ботаника бакчасы (1834), өч башлангыч уч-ще (1831, 1832, 1836), Икенче ир балалар гимназиясе (1835), Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-ты (1841) ачылуга ярдәм итә. Казан икътисадчылар җәмгыяте президенты (1839–41). 1841 дән Сенатның Мәскәү департаментында. Изге Александр Невский ордены б-н бүләкләнә.



С.С. Стрекалов.

*Әд.:* М и х а й л о в И.И. Казанская старина: Из воспоминаний // Рус. старина. 1899. Т. 100; М а л ы ш е в А.А. Губернатор доброго старого времени: Воспоминания старожила // Рус. старина. 1907. Т. 131. *Е.Б.Долгов.*

**СТРЕ́ЛЬНИКОВ** Юрий Петрович (22.3.1947, Куйбышев өлкәсенең Чапаевск ш.), физик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1998), физика-матем. фән. канд. (1990). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Федераль ГИПО ФҖБ Дәүләт унитар пр-тиесендә эшли, әйдәп баручы инженер (1974 тән), цех (1979 дан), бүлек (1989 дан) башлыгы, тәҗрибә з-дының баш оптигы (1998 дән). Хезмәтләре оптик капламнар физикасына һәм технологиясенә карый. С. дифракцион рәшәткәләр өчен алюминий капламнар алу технологиясен эшли. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге голограммалы дифракцион рәшәткәләр әзерләүнең фәнни технологиясе нигезләрен эшләгәне

һәм аны ГИПОның серияләп дифракцион оптика җитештерүенә керткәне өчен бирелә (Россия тармак пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә).

**СТРЕ́ПЕТОВА** Пелагея (сәхнәдә — Полина) Антипьевна (4.10.1850, Түбән Новгород ш. — 4.10.1903, С.-Петербург), драма актрисасы. Сәхнә эшчәнлеген 1865 елда Ярославль губернасының Рыбинск шәһәрендә башлап җибәрә, аннан соң Ярославль, Сембер, Самара, Саратов шәһәрләре театрларында эшли. 1872 нең гыйнварында Казан шәһәр театры сәхнәсендә Н.И. һәм Н.Н.Куликовларның «Гаиләисәп-хисаплары» драмасы буенча куелган спектакльдә беренче тапкыр Анна Петровна роле б-н чыгыш ясый. 1872 нең 17 февралендә А.Ф.Писемскийның «Ачы язмыш» драмасы буенча куелган спектакльдә С.ның Лизавета роле б-н чыгышы Казан театр тормышында зур бер вакыйгага әверелә. Актрисаның сәхнәдә уйнавы Казанда чыга торган барлык газеталарда да теге яки бу рольне тулысынча образга кереп башкаруга, геройның эчке дөньясына тирәнтен үтеп керүгә нигезләнгән яңа драматик сәнгать мәктәбе туура тиң буларак бәяләнә: «...Стрепетова ханым зур талантка ия, аның уенында еш кына әчкерсез, чын кичерешләр һәм табигыйлек, акыл һәм үзенчәлек чагылыш таба... Иллюзия шул дәрәҗәдә чынбарлыкка әверелә ки, син үзеңнең кайда икәнеңне дә, синең каршыңда актриса басып торуын да онытып җибәрәсең, сиңа ул хакыйкый тормыштагы кайгы-хәсрәтләр, шик-шөбһәләр б-н басылган, изелгән чын кеше буларак күзаллана, һәм аның күңелне өшетерлек олы хәсрәтеннән коточкыч куркыныч булып китә» («Казанский биржевой листок», 1872, № 9). 1874–75 тәге сезонда Казанда А.Н.Островскийның «Яшенле яңгыр» пьесасы буенча куелган спектакльдә Катерина ролен уңышлы башкарып чыга. Бу роле аркылы С.ның трагик характерларны уйнарга сәләтле булуы ачыла. Актриса Казан сәхнәсендә ш.у. Людмила, Мария, Аннушка («Кичеккән мәхәббәт», «Ярлы кәләш», «Кеше күп җыелган җирдә», А.Н.Островский), Лиза («Акыллылык бәласе», А.С.Грибоедов), Верочка («Бала», П.Д.Боборыкин), Луиза («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер) рольләрен дә башкара. С. чыгышлары алдынгы карашлы Казан зыялылары һәм студентлары тарафыннан хатын-кызларның хокуксызлыгына карата каршылык белдерү, көнүзәк социаль проблемаларны хәл итәргә чакыру кебек кабул ителә, театраль Россия масштабында киң яңгыраш ала. Аннан соңгы елларда Мәскәү театрлары сәхнәләрендә һәм С.-Петербургтагы Александра театрында уйный, рус театр сәнгате тарихында якты эз калдыра.

Х е з м.: Воспоминания и письма. М.–Л., 1934.

*Әд.:* К р у т и И. Русский театр в Казани. М., 1958; Б е н ь я ш Р. Пелагея Стрепетова. Л., 1967; Б л а г о в Ю. «...получил прозвище Казанский». К., 2001; Театральная энциклопедия. М., 1965. Т. 4.

*Ю.А.Благов.*

**СТРИЖЕ́ВСКИЙ** Михаил Васильевич (18.2.1853, Воронеж ш. — 30.8.1913, Бад-Наугейм ш., Германия), дәүләт эшлеклесе, хакыйкый статский советник (1907). Дворяннар катлавыннан. 1871–1904 елларда Воронеж губернасының Бобров өязендә: җәмәгать судьялары съездында секретарь ярдәмчесе (1876 га кадәр), 1876–81, 1889–91 елларда крәстияннәр эшләре буенча өяз кабулханәсе әгъзасы, 1885–89 да участок җәмәгать судьясы, 1891–1901 дә земство башлыгы, 1901 дән өяз дворяннары җитәкчесе. 1904–06 да Пермь вице-губернаторы. 1906 дан Казан губернаторы. Төрле революцион чыгышларны бастыру, *Столыпинның аграр реформасын* уздыру, Казан губернасында 1–4 Дәүләт Думасына сайлаулар уздыру б-н җитәкчелек итә. «Идел буе төбәгендә мөселман татар йогынтысына каршы чаралар билгеләүче киңәшмә»дә (1910) һәм Россиядә мәктәп реформасын әзерләүдә (төбәтә яшәүчеләрнең милли һәм дини үзенчәлекләрен исәпкә алмыйча гына, башлангыч һәм урта белемне берләштерүне күз алдында тота) катнаша. Изге Гурий Борадәрлеге эшчәнлегенә ярдәм күрсәтә. Казанда Югары хатын-кызлар курслары (1906), Рус музыка җәмгыяте бүлеге (1906), зоопарк (1907), Ягодный бистәсендә балалар ятимханәсе (1907), Халыкара вак һөнәрчелек сәнәгате һәм түбән һөнәри белем күргәзмәсе (1909), Шамов хастаханәсе (1910) ачылуга, «Волжско-Камская речь» г-тасын нәшер итүгә (1907), Идел аша Романов тимер юл күпере төзүгә (1911–13) булышлык күрсәтә. Казан ярлыларны кайгырту попечительләр ком-ты попечителе (1908 дән).

*Әд.:* Д о л г о в Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «вручённой на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б.Долгов.*



П.А.Стрепетова.



М.В.Стрижевский.



Д.Е.Строганов.

**СТРО́ГАНОВ** Виктор Фёдорович (31.12.1940, Кырым АССРның Саки штп), химик-технолог, химия фән. д-ры (1989), проф. (1993), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2002), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2007). 1963 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Я.М.Свердлов исем. з-дта эшли (Горький өлкәсенең Дзержинск ш.). 1970 тән Дзержинск химия-технол. фәнни-тикшеренү ин-тында (сектор һәм лаб. башлыгы), 1979 дан Украина пластик массалар фәнни-тикшеренү ин-тында (Донецк ш.) җилемнәр һәм компаундлар бүлеге башлыгы. 1995 тән Казан архит-ра-төзелеш ун-тында: проректор, химия һәм төзелештә инженерлык экологиясе каф. мөдире (2006 дан). Россия архит-ра-төзелеш фәннәре академиясе киңәшчесе (2003 тән). Хезмәтләре полимер композицион материалларга карый. С. нитроэпоксид сумалалар һәм алар нигезендә полимерлар синтезлый, аларны тикшерә. Аның җитәкчелегендә полимер композицион материаллардан махсус техника технологияләре һәм эшләнмәләре, күмер чыгару сәнәгате өчен саклагыч шартлаткыч матдә составлары, вюрцитсыман бор нитриды (үтә каты абразив материал) технологиясе булдырыла. Эпоксид полимерларда зур адамант фрагментлары булган, ш.у. макромолекула чылбырында гидроксиуретан һәм аллил фрагментлары булган полимер-полимер адгезивлар табуның фәнни нигезләрен эшли. Эпоксид сумалаларны киптерү һәм аларны җитештерүдә су чыгымын киметү юлларын; агызып җәелгән җөйсез полимер идән композицияләрен; оптик сүс технологияләрендә, ракета техникасында, суднолар төзелешендә һәм халык хуҗалыгының башка тармакларында куллану өчен төрле эпоксид җилемнәр һәм компаундлар; газ сәнәгате өчен адгезивлар; төзелеш өчен композицион материаллар эшли һәм гамәлгә кертә. Уйлап табуга 120 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Взаимная пластификация полимер-полимерных систем с высокой удельной функциональностью // Докл. АН СССР. 1987. Т. 292, № 33 (автордаш); Исследование эпоксидно-аллиловых предполимеров для последовательных взаимопроникающих сеток методом импульсного ЯМР // Высокомолекулярные соединения. 1995. Т. 37А, № 10 (автордаш); Эпоксидные полимеры на основе адамантана // Успехи химии адамантана. М., 2007 (автордаш).

**СТРО́ГАНОВ** Дмитрий Евгеньевич (30.8.1910, Казан — 17.8.1948, Мәскәү), Сов. Союзы Герое (7.4.1940), полковник. Кече лейтенантлар курсын тәмамлый (Мәскәү, 1935). Типографиядә хәреф җыючы булып эшли (Мәскәү). 1933 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша, 291 нче җиңел артиллерия полкында (13 нче армиянең 136 нчы укчы дивизиясе) батарея командиры. Төньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре составында Ильвес һәм Кююрёль янындагы ныгытылган районнарны үтү өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә: 1940 ның 11–17 февралендә пулемёт уты б-н укчы подразделениеләрнең һөҗүменә булыша, берничә дотны һәм ут ноктасын, дошманның зур сандагы тере көчләрен юк итә. Бөек Ватан сугышы елларында Мәскәү Хәрби округы штабында хезмәт итә. 1945 тән запаста, Мәскәү энергетика ин-тында эшли. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СТРОМАТОЛИТЛА́Р** (грек. stróma — аслык һәм *лито*...), сулыклар төбендәге кабарынкы яки тигезсез өслекле һәм катлаулы катламлы карбонат утырмалары. Түбән төзелешле суүсемнәрдән һәм суүсем җепселләре б-н бактерияләр арасында тупланган химик һәм механик карбонаттан барлыкка килә. Татарстан терр-ясендә борынгы рифейның (1400 млн. ел) утырма токымнарында, 3 мең *м* тирәнлектән башлап очрыйлар. Стратиграфиядә утырмаларны чагыштыру һәм аеру өчен кулланыла.

*Әд.:* Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003.

**СТРУ́ВЕ** (Struve) Фёдор Аристович (Эрастович) (Jakob Theodor) (24.5.1816, Фленсбург, Дания — декабрь 1884, башка чыганакларда, 22.12.1885, Рига), филолог, классик филол. д-ры (1846), проф. (1855), статский советник (1860). Танылган Россия астрономы В.Я.Струвеның бертуганының улы. Дерпт ун-тын тәмамлый (1837). 1844 елдан Казанда: Беренче ир балалар гимназиясендә латин теле укытучысы, бер үк вакытта Казан ун-ты укытучысы, 1855–57 дә тарих-филол. ф-ты деканы; 1856–61 дә Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында немец теле укыта. С.ның грек филологиясенә багышланган хезмәтләре «Казан университетының гыйльми язмалары» («Учёные записки Казанского университета») җыентыгында басыла. 1862 дә, студентларның тәртипсезлекләреннән соң, «тәртибендә акыл һәм такт юклыгы...» сәбәпле университеттан куыла. С.-Петербургта, Одессада яши һәм эшли (1865–70 тә Новороссийск ун-тының грек теле, әдәбияты, сәнгать теориясе һәм тарихы каф. профессоры). 2 нче дәрәҗә Изге Станислав ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Списки чиновников и преподавателей Казанского учебного округа... К., 1861; К о р б у т М.К. Казанский государственный университет имени В.И.Ульянова-Ленина за 125 лет (1804/05 — 1929/30). К., 1930. Т. 1.

*И.А.Новицкая.*

**СТРУКТУ́Р КА́РТА**, җир астының геол. төзелеше, тектоникасы турында мәгълүмат бирә һәм җир асты терәк горизонты рельефын изогипсларда күрсәтә торган сызым. С.к. файдалы казылмаларны, еш кына нефть һәм газны эзләүдә, разведкалау һәм файдалануда күбрәк нәтиҗәләр алу өчен төзелә. Аеруча җиңел һәм хәрәкәтчән углеводородлар катламнар һәм ярыклар буенча күчү процессында еш кына катлам-коллекторларның гөмбәзсыман участокларында тупланалар һәм ятмалар хасил итәләр. Югары горизонтлар буенча гөмбәзләр, гадәттә, тирәндәрәк булган катламнарда туры (яки үзгәргән) калкулыклы участокларны чагылдыралар. Күтәренке участокларны ачыклау өчен, беренче этапта 50–600 *м* тирәнлектә структур-карталау алымы б-н бораулау үткәрәләр, гөмбәзләрне ачыклагач, тагын да тирәнрәк скважиналар бораулыйлар. ТРда Пермь утырмалары буенча беренче С.к. Идел буенда нефть эзләү эшләренең җәелүе б-н бәйле рәвештә 1930 елларда төзелә, соңрак тирән бораулау һәм геофизик мәгълүматлар нәтиҗәсе буенча С.к. карбон, девонның тагын да борынгырак утырмаларының аерым горизонтлары һәм кристаллик нигез түбәсе буенча төзелә башлый. С.к. беренче нефть чыганакларын, ш.и. Россиянең Европа өлешендә иң зур Ромашкино чыганагын ачыкларга мөмкинлек бирә.

**СТРУМИ́НСКИЙ** Василий Яковлевич (1.1.1880, Каменец-Подольск губ., Могилёв өязе Кошаринцы а. — 19.7.1967, Мәскәү), педагог, дин белеме магистры (1906), пед. фән. д-ры (1967), ПФА мөхбир әгъзасы (1945). Мәскәү руханилар академиясен тәмамлаганнан соң, 1903 елдан — Пермь, 1907 дән Оренбург руханилар семинарияләрендә укыта. 1919–26 да Оренбург халык мәгарифе ин-ты һәм кыз балалар гимназиясе директоры. 1926–32 дә Шәрекъ пед. ин-тының пед. каф. мөдире (Казан), проф. (1926). С. җитәкчелегендә ТАССРда совет педагогика фәне булдырыла, педагогиканы татар телендә укыту оештырыла. 1933–67 дә Мәскәүдә ПФА фәнни-тикшеренү ин-тларында фәнни хезмәткәр. Рев-циягә кадәр агиографияне өйрәнә, «Вятка могҗиза тудыручысы изге Трифон атакайның тормышы» («Житие преподобного отца нашего Трифона Вятского Чудотворца») хезмәтен төзи һәм бастыра (Пермь, 1906). Оренбург һәм Казанда Совет педагогикасы теориясе проблемалары б-н шөгыльләнә. Мәскәү чорындагы хезмәтләре пед. тарихына багышлана. К.Д.Ушинскийның фәнни биографиясе авторы, аның хезмәтләрен басмага әзерли.

Х е з м.: Хрестоматия по основным вопросам теории и практики трудовой школы: В 3 ч. Л., 1924; В поисках марксистской методологии в педагогике. М., 1930; Теоретическая дискуссия в советской педагогике. М., 1930; Очерк жизни и педагогической деятельности К.Д.Ушинского. М., 1961.

*Әд.:* В.Я.Струминский: Биобиблиогр. М., 1980.

**СТУДЕНЕ́Ц** елгасы, Идел алдында, Зөя елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 14,1 *км*, бассейнының мәйданы 71,1 *км*$^2$. Буа р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Яңа Суыксу авылыннан 6 *км* көнбатыштарак, тамагы Ивашевка авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 130 *м*, тамагыныкы — 66 *м*. Су җыелу мәйданында урман үсемлекләре үсми диярлек. С.ның 0,8 *км* озынлыктагы 1 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,21 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, өчтән ике өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана, коры вакытта елганың түбән агымы кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 77 *мм*, ташу агымы катламы 49 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,03 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. С. бассейнында суының гомуми күләме 0,6 млн. *м*$^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла. С.ның тамак өлешендә *Ивашев В.П. утар-паркы* табигать истәлеге урнашкан.

**СТУДЕНЕ́Ц** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 5 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 23 кеше (руслар) яши. 1646 дан мәгълүм. Халкы башта Зөя Троица Сергий монастырена карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, бакчачылык, Казанда сату өчен җиләк үстерү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.та укырга-язарга өйрәтү мәктәбе (1900 дә ачыла), җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 504 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Югары Ослан волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1646 һәм 1782 дә — 66 шар ир-ат; 1859 да — 146, 1897 дә — 199, 1908 дә — 247, 1920 дә — 319, 1926 да — 222, 1938 дә — 370, 1949 да — 329, 1958 дә — 257, 1970 тә — 171, 1979 да — 118, 1989 да — 49, 2002 дә — 22 кеше.

**СТУДЕ́НСКИЙ** Михаил Николаевич (12.9.1945, Балык Бистәсе р-ны Балык Бистәсе а.), тау эшләре инженеры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006), РФнең атказ. рационализаторы (1993). Уфа нефть ин-тын тәмамлый (1972). Хезмәт эшчәнлеген 1965 елда «Мангышлакнефть» ҖБнең Узень геол. разведкасы экспедициясендә бораулаучы ярдәмчесе буларак башлый. 1966–2000 дә Әлмәт бораулау эшләре идарәсендә бораулаучы ярдәмчесе, тирәнлеккә бораулаучы, бораулау мастеры, смена башлыгы урынбасары, район инженер-технол. хезмәте башлыгы урынбасары, башлыгы, баш инженер, «Татнефть» АҖ ген. директорының бораулау буенча урынбасары (2000 нән), бер үк вакытта «Татнефть-Бораулау» ҖЧҖ директоры (Әлмәт ш., 2002 дән). Дәүләт бүләге нефть һәм газ скважиналарын киңәюче махсус торбалар кулланып ныгыту максатында яңа технологияләр һәм техник чаралар эшләве һәм гамәлгә кертүе өчен бирелә. Медаль, ТР Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**СТУДЕ́НСКИЙ** Николай Иванович (1844, Пенза — 17.9.1891, Казан), хирург, медицина д-ры (1873). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1869), госпиталь хирургиясе клиникасында проф. М.В.Никольский кул астында эшли, бер үк вакытта земство фельдшерлар мәктәбендә укыта, десмургия һәм ортопедия курслары (бәйләвечләр һәм сынулар турында) алып бара. 1876 елда Казан ирекле сан. отряды б-н җитәкчелек итә һәм Сербиядә яралыларны дәвалауда катнаша. Рус-төрек сугышы вакытында, 1877–78 дә, Румыния хәрби госпитальләрендә эшли. 1884 тән Казан ун-тының оператив хирургия каф. мөдире, бер үк вакытта Александр исем. шәһәр хастаханәсендә студентлар б-н клиник дәресләр алып бара, шунда Казанда беренче булып антисептика ысулын куллана, яңа ринопластика ысулын эшли; 1887 дә госпиталь хирургия клиникасы директоры итеп билгеләнә. Хезмәтләре гигиена, десмургия, пластик хирургия, травматология, те-

рәк-хәрәкәт аппараты авырулары һәм җәрәхәтләре, урологиягә карый. «Император Казан университеты каршындагы Казан табибләр җәмгыяте көндәлеге»н («Дневник Казанского общества врачей при Императорском Казанском университете») нәшер итүне башлап йөрүчеләрнең берсе; студентлар китапханәсе эшенә җитәкчелек итә.

Х е з м.: Хирургические повязки. К., 1876; Фунгозное воспаление позвоночника. К., 1880; Огнестрельные повреждения костей и суставов на конечностях. К., 1881; Курс ортопедии. СПб., 1885; Курс оперативной хирургии. К., 1888.

*Әд.:* Р ы б а к о в В.И. Из военно-хирургического наследия Н.И.Студенского // Казан мед. журн. 1958. № 4.

**«СТУДЕ́НТ КомВУ́ЗА»**, журнал; к. «*КОМВУЗ студенты*».

**«СТУДЕ́НТ ТКУ»**, журнал; к. «*КОМВУЗ студенты*».

**СТУДЕНТЛА́Р ҖЫЕННАРЫ́**, Россия студентларының 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башында администрациягә карата иҗтимагый-сәяси таләпләр кую хәрәкәте. Беренче җыен 1856–57 елларда Петербург ун-тында уза, анда попечитель Г.А.Щербатов тарафыннан студентларга аена 2 тапкыр җыелырга рөхсәт бирелә. Уку биналарында куелган полиция-сак режимы, чикләүле чаралар (студентлар составын катлау, милләт, яшь буенча көйләп тору, профессорлар коллегиясе автономиясен даими кысу) югары уку йортларын илдә хөкем сөргән сәяси тәртипләргә каршы оештырылган фетнә чыганакларының берсенә әверелдерә. С.җ. акрынлап, югары уку йортлары эчендәге проблемалар чигеннән чыгып, самодержавиегә каршы юнәлдерелгән сәяси лозунглар һәм гамәлләргә әверелә. Әлеге процесска җәмгыятьнең урта һәм түбән катлауларыннан чыккан студентларның артуы да этәргеч ясый, ш.у. моңа революцион-демократик һәм соц. идеяләр таралу шартларында формалашкан яңа буын булышлык итә. Казан ун-тында беренче С.җ. 1857 нең гыйнварында уза; ул вакытта студентларның ун-т администрациясе б-н бәрелеше була. Казанда иң зур С.җ. 1889, 1901, 1902, 1910, 1917 елларда булып уза. Ш.у.к. *Казан студентлары җыены (1887)*.

*С.М.Михайлова.*

**СТУДЕНЦО́В** Андрей Петрович (25.11.1903, Казан губ., Спас өязе Кокрять а. — 8.12.1967, Казан), вет. акушеры, вет. фән. д-ры (1937), проф. (1933), ВАСХНИЛның мөхбир әгъзасы (1956), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1945, 1960). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1925), шунда ук эшли, акушерлык каф. мөдире (1935–67). Вет. акушерларының Казан фәнни мәктәбен нигезләүчеләрдән берсе. А.х. терлекләрендә кысырлык, абортлар, маститларның яңа классификациясен эшли; көтүне яңарту интенсификациясе мәсьәләләрен өйрәнү б-н шөгыльләнә. Югары уку йортлары өчен «Ветеринария акушерлыгы һәм гинекология» («Ветеринарное акушерство и гинекология», М., 1949; 7 нче басма, М., 1999) дәреслеге авторы. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1950). Ленин ордены, өч Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Аборты лошадей и других с.-х. животных. К., 1947; Диагностика беременности и бесплодия сельскохозяйственных животных. М., 1950; Болезни вымени коровы. М., 1952.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*М.Г.Миролюбов.*



А.П. Студенцов.

**СТУДЕНЦО́ВА** Ирина Андреевна (1.5.1933, Казан — 17.12.2002, шунда ук), фармаколог, мед. фән. д-ры (1976), проф. (1978), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). Профессорлар Н.В.Лазарев (С.-Петербург) һәм И.В.*Заиконникова* шәкерте (Казан). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1958), шунда ук фармакол. кафедрасында эшли. Хезмәтләре синтетик фосфорорганик кушылмаларның биол. активлыгын өйрәнүгә карый. А.Е.Арбузов исем. Органик һәм физик химия ин-ты химиклары һәм Казан мед. ун-ты фармакологлары һәм клиницистларының антихолинэстеразалы тәэсире булмаган фосфорорганик кушылмалар нигезендә дару матдәләре (глицифон, *димефосфон*, мифопран; медицинада гамәлгә кертеләләр) ясау мөмкинлеге концепциясен тудырган уртак тикшеренүләре нәтиҗәләрен гомумиләштерә. Уйлап табуга 15 авторлык таныклыгы һәм патенты, 4 чит ил (Англия, Япония, Германия, Швейцария) патенты бар. «Димефосфон — нерв системасы функцияләрен көйләүче оригиналь дару матдәсе» («Димефосфон — оригинальный лекарственный препарат, нормализующий функции нервной системы») хезмәте өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (1994).


Х е з м.: Фосфорорганические соединения с низкой токсичностью // Докл. АН СССР. 1965. Т. 165, № 1 (автордаш); Экспериментальное обоснование применения цидифоса для лечения злокачественных новообразований // Химиотерапия опухолей в СССР. 1970. Вып. 7–8 (автордаш); Димефосфон — препарат выбора при заболеваниях нервной системы // Terra medica nova. 2000. № 1.

*Әд.:* Г а р а е в Р.С., З у б а и р о в Д.М. Профессор Ирина Андреевна Студенцова: Некролог // Казан. мед. журн. 2003. № 2.

**СТУ́ПИН** Рафаил Александрович (12.4.1798, Түбән Новгород губ. Арзамас ш. — 1860 еллар башы), график, педагог. Арзамас шәһәрендә Россиядәге беренче провинциаль сәнгать мәктәбе оештырып танылган рәссам А.В.Ступинның улы (1802–61). 1809 елдан САдә (С.-Петербург) укый. 1818 дә, академияне тәмамларга бер ел кала, уку турында таныклык б-н азат ителә, 1829 да әтисенең үтенече буенча, 1 нче дәрәҗә аттестат б-н тарихи нәкышь рәссамы дәрәҗәсе ала. 1819–29 да А.В.Ступинның Арзамас мәктәбендә укыта. Перспектив һәм натурадан төшерү класслары ача, әйдәп баручы новатор-укытучыларның берсе була (сызым дәресен эстамп б-н бергә укыту, дәреслектәге рәсемнең оригиналына карата сурәтнең масштабын зурайту һәм кечерәйтү алымнарын кертә). Мәктәптә укыту матодларын җентекләп бәян иткән һәм системага салган «Рәсем һәм нәкышь, натурадан карап рәсемгә төшерү һәм акварель портретлар курсы» («Курс рисования и живописи, рисунков с натуры и акварельных портретов») кульязмасы авторы (1820 еллар ахыры). Җәй көне әтисе һәм укучылары б-н бергә Россиянең төрле төбәкләрендә, ш.и. Казан монастырьларында иконалар ясау б-н шөгыльләнә («тарихи картиналар» яза, диварлар бизи), 1822–23 тә Арзамас мәктәбенең укытучылар һәм укучылар төркеме составында Түбән Новгород ярминкәсендәге Яңа собор чиркәве диварын бизәүдә катнаша. С. укучыларны хезмәткә күнектерә, әдәбиятны, шигъриятне яратырга өйрәтә. Мәктәптән киткәч, Идел буе шәһәрләрендә була, заказлар буенча акварель һәм майлы буяу б-н портретлар яза. 1830 елларның 2 нче яртысыннан Казандагы дусты арх. Н.П.Коринфскийда яши. Күп санлы портретлар яза; күпчелегенең саклау урыны билгесез, музей тупланмаларында сакланып кал-



Р.А. С т у п и н. «Хатын-кыз портреты». 1846. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.



Р.А. С т у п и н. «Сәүдәгәр портреты». 1850 еллар. ТР Милли музее.

ганнары арасында — «И.В.Жмакин портреты» (1838), «Яшь сәүдәгәр портреты» (1847) һәм «Ачык изүле яшел күлмәк кигән ак шарфлы яшь ханым портреты» (1840 еллар; әлеге ике портретның ирле-хатынлы Казан сәүдәгәрләре Батуриннарга нисбәтле булуы ихтимал), «Хатын-кыз портреты» (1846), «Ир-ат портреты» (1851), «Сәүдәгәр портреты», 2 хатын-кыз портреты (1850 еллар; барлык өч әсәрдә дә танылган Казан сәүдәгәре Крупеников гаиләсе вәкилләре сурәтләнгән булуы ихтимал) һ.б.

1820–30 елларда язылган акварель портретлары башкару алымының җиңел һәм йомшак булуы, рәсемнең проф. дәрәҗәдә эшләнүе, сызыкларның сыгылмалылыгы һәм буяуларның яңалыгы б-н аерылып торалар. С.ның 1850 еллардагы портрет иҗаты 19 йөз уртасы гади рус портретының стилистик сыйфатларын чагылдыра (композицияләрнең кануни катгыйлыгы, конкрет образга басым ясаганда, рәсемнең камил булмавы, портреттагыларның кысылган, яссы формасы һәм рухсыз-җансыз статик позасы, кием һәм башка аксессуарлардагы кирәгеннән артык детальләштерү, колоритта — гомуми нейтраль фонда куе, җирле төстәге тапларның тәңгәллеге). Кайбер әсәрләрендә Европадагы бидермейер стиле йогынтысы тоемлана («Сәүдәгәр хатыны портреты», 1846). 1850 еллардан тыгыз гадирәк алым б-н эшләве, майлы буяу б-н башкарылган нәкышькә якынлыгы аның акварель өлкәсендәге иҗатының да үзенчәлекле сыйфаты булып тора. С. акварельләренең нокталы миниатюр техникасы аның соңгы әсәрләрендә тупасрак зурайтылган формаларда үзенчәлекле чагылыш таба.

Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, А.Н.Радищев исем. сәнгать музеенда (Саратов ш.), Түбән Новгород сәнгать музеенда, Арзамас тарихи-сәнгать музеенда, Мәскәү һәм С.-Петербург музейларында саклана.

*Әд.:* З а й ц е в И.К. Воспоминания старого учителя // Рус. старина. 1887. № 6; К о р н и л о в П.Е. Рафаил Александрович Ступин // Казан. музейный вестн. 1924. № 1; ш у л у к. Арзамасская школа живописи первой половины XIX века. Л.-М., 1947.
*И.Ф.Лобашёва.*

**СТУПИ́ШИН** Александр Владимирович (13.6.1912, Псков ш. — 14.12.1992, Казан), географ, геогр. фән. д-ры (1957), проф. (1958), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1972). Казан ун-тын тәмамлый (1936), шунда ук эшли, физик геогр. каф. мөдире (1951–82). Хезмәтләре Урта Идел буе рельефы, карсты, Куйбышев сусаклагычы ярларының геоморфологиясе, бу терр-яләрне физик-геогр. районлаштыру мәсьәләләренә карый. С. карстка комплекслы сыйфатлама бирә, тигезлек һәм тау типларының үзенчәлекләрен күрсәтә, Татарстанда хәзерге заман карст үсешенең 4 төп зонасын (Идел буе, Зөя, Көнбатыш Кама алды, Көнчыгыш Кама алды) билгели. Районлаштыру берәмлекләре системасын эшли, Урта Идел буе районнарының физик-геогр. карта-схемасын төзи. Геогр. үсеше тарихына, геогр. ачышларга, фәнни мәсьәләләрне хәл итүгә багышланган, геогр. тикшеренүләрнең приборлар базасын булдыру һ.б. буенча фәнни хезмәтләр авторы. СССР География җәмгыятенең Татарстан ф-лы рәисе (1961 елдан), аның шәрәфле әгъзасы (1980 нән). «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сюкеевские пещеры. К., 1950 (автордаш); Равнинный карст и закономерности его развития на примере Среднего Поволжья. К., 1967; Географическая характеристика административных районов Татарской АССР. К., 1972.

*Әд.:* М о з ж е р и н В.И., К о ж е в а т о в Е.Д., Т о р с у е в Н.П. Александр Владимирович Ступишин. К., 2004.

**СУ АНАСЫ́**, татар мифологиясендә су ияләренең бер төре (башка исеме — *су иясе*). С.а.ның ире — *су бабасы* һәм балалары бар (кайвакыт алар да су иясе дип аталалар). С.а. зур озынча башлы, кашсыз зур кара күзле, киң күкрәкле, бакыр кебек кызгылт гәүдәле ямьсез хатын-кыз буларак күзаллана. Татар фольклорының берничә гадәти сюжетында катнаша. С.а.ның алыштыргысыз атрибуты — үзенең озын чәчен тарый торган алтын тарагы. Су коенучы балаларны су астына тартып, аларның канын эчә. Г.Тукай һәм Г.Сөнгатинең шул ук исем. поэмалары, З.Хәкимнең «Су төбендә сөйгәнем» (1992) пьесасы персонажы.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987; Б а я з и т о в а Ф.С. Себер татарлары: Рухи мирас: Гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. К., 2001; Мифы народов мира. М., 1988. Т. 2. *Ф.И.Урманчеев.*

**«СУ АНАСЫ́»**, композитор Ә.З.Бакировның 3 күренешле прологлы балеты. Г.Тукайның шул исем. поэмасы һәм татар халык әкиятләре буенча И.В.Смирнов либреттосы драматик вакыйгаларга бай, анда ярлы егет б-н кызның әкияти явыз көчләргә каршы мәхәббәт һәм бәхет өчен көрәше турында бәян ителә. Премьерасы Татар опера һәм балет театрында була (1971). Балетмейстер-куючысы — И.В.Смирнов, дирижёры — Х.В.Фазлуллин, рәссамы — Б.Г.Кноблок, костюмнар рәссамы — А.Б.Кноблок. Төп партияләрне С.Х.Хантимирова, Л.Н.Хуторова (Сәрви), Р.Ф.Садыйков, К.Г.Гайнуллин, Н.С.Сәрвәров (Алмай), Г.С.Калашникова, Р.М.Новицкая (Су анасы) башкара. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә авторлар, дирижёр, рәссам һәм артист Р.Ф.Садыйков лаек була. Балет репертуарыннан 1981 елга кадәр төшми.



«Су анасы» балетыннан күренеш.
(Су анасы ролендә – Г.С. Калашникова,
Морза – В.Е. Шкилько). 1971.

**СУ БАБАСЫ́**, татар мифологиясендә су ияләренең бер төре, аларның башлыгы. Тирән сулыкларда гына яши. С.б. үзен борчыганны, үртәгәнне, яшәгән урыны янына якын килгәнне өнәми. Аны борчысалар, ул шунда ук рәхимсезлеген күрсәтә, суда давыл куптарып, чоңгылга тартып алырга мөмкин. С.б.н тынычландыру өчен корбан бирергә, суга он һәм тоз катыштырып салырга кирәк дип ышанганнар. Он катыш тоз С.б. яши торган сулыкларда тәндә барлыкка килгән яра һәм сулы шешләрне бетерә, имеш. Яраларга тоз-он сипкәндә, өч тапкыр «Каян чыктыгыз, шунда югалыгыз», — дип кабатлаганнар.

*Әд.:* Н а с ы й р и К. Казан татарларының тормышында Ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр // Сайланма әсәрләр. К., 1975. 2 т.; Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987.

**СУ БАЛТЫРГАНЫ́**, сәрәтә (Cicuta), чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 10 га якын төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — агулы С.б. (C. virosa) бар. Барлык районнарда да очрый. Сазлыклы болыннарда, торфлы һәм күрәнле сазлыкларда, кечкенә култык буйларында үсә. 60–120 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы вертикаль, камераларында аркылы бусагалар б-н бүленгән. Сабагы куыш, туры, кабыргалы. Яфраклары икешәр яки өчәр каурыйсыман. Чәчәкләре вак, ак, катлаулы чатырга җыйналган. Җимеше — яссы кабыргалы йомры ике орлыкча. Июнь–августта чәчәк ата. Күбесенчә орлыктан үрчи. Үсемлекнең барлык өлешләрендә цикутотоксин — сумалалы матдә бар, ул исә йорт хайваннарында һәм кешедә көчле, еш кына үлемгә китерүче (буылып үләләр) агулану китереп чыгара.

**СУ БАСУЛА́Р**, су биеклегенең (елга, күл, диңгез) күтәрелүе нәтиҗәсендә җирлекнең су астында калуы. С.б. гаять сулы елларда кар эрегән вакытта көчле су агымы, җәйге мул яңгырлар, ш.у. елгада боз тыгылу нәтиҗәсендә күзәтелә. Кайбер тигезлек елгаларының тамак өлешендә диңгез ягыннан искән җилнең суны кууы аркасында да С.б. була. ТР терр-ясендә С.б. язын, кар эрегән вакытта, кече һәм уртача зурлыктагы елгаларның ташуы б-н бәйле. Гадәттә, зур булмаган мәйданнарны каплый һәм су артык күтәрелми. Зур С.б. уртача 20–25 елга бер тапкыр була һәм елга үзәннәренең чагыштырмача зур участокларында су асты эшчәнлеген боза, шактый гына матди зыян сала, хәтта кайвакыт халыкны да эвакуацияләргә туры килә. 20 йөзнең соңгы чирегендә — 1979 һәм 1990 елларда көчле С.б. була. С.б. б-н көрәштә аеруча нәтиҗәле ысул булып елга агымын көйләү тора. Моның өчен елгаларда сусаклагычлар төзү таләп ителә, алар исә ташу вакытында су-



Казанда су басу (май 1926): 1. Георгий урамы (хәзерге Петербург урамы); 2. Болакта ташу.

ның бер өлешен тоткарлыйлар («ташу пигын өзәләр»). Иделдә Куйбышев сусаклагычы төзелү б-н экстремаль С.б. куркынычы бетерелә (моңа кадәр көчле С.б. 1908, 1926 да була). Боз тыгылуны булдырмас өчен елга юлларын турылау, ягъни турайту, чистарту һәм тыгылу булырга мөмкин урыннарны тирәнәйтү эшләре үткәрелә; ш.у. бозны махсус шартлаталар яки боз китү алдыннан махсус суднолар ярдәмендә аны вак кисәкләргә ваталар. *Ф.Г.Борһанов.*

**СУ БОРЫЧЫ́** (Eiatine), үргәләкчәләр семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 26 төре билгеле, ике ярымшарның да уртача һәм тропик поясларында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар. Дымлы җир С.б. (E. alsinastrum) Кама алдында һәм Идел алдында, үрмәле С.б. (E. hydropiper) Көнбатыш Кама алдында очрый. Күл, буа, елга, элекке елга юлларында, сазлыкларда үсә. Дымлы җир С.б.ның биеклеге 5–30 *см*. Сабагы туры яки күтәрелмә, төбендә ботаклы, куе яфраклы. Яфраклары бөҗралы, 8–12 шәрләп бөҗрага урнашканнар, су астындагылар — бер, су өстендәгеләр 3–7 сеңерле. Үрмәле С.б.ның биеклеге 2–4 *см*. Сабагы шуышма яки күтәрелмә, тармаклы, каршыдаш, озынча түгәрәк яки калаксыман, озын сапларда. С.б.ның чәчәкләре яшькелт-ак яки ак төстә, вак, куентылы, ике катлы чәчәк тирәлекле. Җимеше — яньчек шарсыман тартмачык. Июнь–августта чәчәк аталар. Җимешләре июльдән сентябрьгә кадәр өлгерә. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**СУ БОРЧАЛАРЫ́**, к. *Дафнияләр*.

**СУ ИШӘКЧЕГЕ́** (Asellus aquaticus), тигезаяклылар (югары төзелешле кыслалар) отрядыннан кыслачык. Киң таралган Европа төре, ТРда барлык җирдә дә очрый. Зур булмаган күлләр, акрын агымлы елга буйларындагы үсемлекләр арасында яши. Гәүдәсе туры, кысылган, коңгырт төстә. Ата затлар (17–20 *мм*) аналарына (12–15 *мм*) караганда зуррак. Йөргүгә җайлашкан һәм бертөрле диярлек 7 пар аягы бар. Озын 4 мыекчыгын алга сузып хәрәкәтләнә. Суга коелган һәм череп ятучы агач яфракларын, ш.у. су үсемлекләрен һәм детритны ашап, сулыкларны чистарта.

*Әд.:* Б и р ш т е й н Я.А. Пресноводные ослики (Asellota) // Фауна СССР. Ракообразные. М.–Л., 1951. Т. 7, вып. 5; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Определитель пресноводных беспозвоночных России и сопредельных территорий: Ракообразные. СПб., 1995. Т. 2. *Р.М.Сабиров.*

**СУ ИЯСЕ́** (су хуҗасы), Казан, Көнбатыш Себер татарларында, башкортларда, казакъларда һ.б. халыкларда су рухы; ияләрнең бер төре. Борынгы су культы б-н бәйле. С.и. сулыклар булган һәр җирдә бар дип саналган; аның яшәү урынына керү урыны төптә, таш астында, имеш. Кеше кыяфәтенә керергә мөмкин. Бик бай. Базар буйлап йөреп, тәм-том һәм җиләк-җимеш сатып ала. Суда шаяра, шау-шу куптара. Берәр кешегә ачуланса яки үпкәләсә, аңа зыян китерергә, балыкларны куып алып китәргә, су тегермәннәренә зыян салырга, малларны, кешеләрне суга батырып үтерергә мөкин. С.и.нең күңелен күрер өчен, беренче тапкыр су алыр алдыннан елга яки күлгә тимер акча, тасма яки сакалдан бер төк тартып алып салырга кирәк. С.и. ир-ат затына (*су бабасы*) һәм хатын-кыз затына (*су анасы*) аерыла.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987; Мифы народов мира. М., 1988. Т. 2.

**СУ ЙОЛДЫЗЫ́**, к. *Саз йолдызы.*

**СУ КӘБЕСТӘСЕ́** (Potamogeton), су кәбестәчәләре семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 100 гә якын төре билгеле, бөтен Җир шарында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 29 төре бар. Ялтыравык С.к. (P. lucens), йөзгәләк С.к. (P. natans), сырлы С.к. (P. pectinatus) һ.б. барлык р-ннарда очрыйлар. Ике формалы (двухформный) С.к. (P. biformis), йогышсыз С.к. (P. fluitans), Циц С.к. (P. zizii) һ.б. — сирәк төрләр. Агымсыз һәм әкрен агымлы сулыкларда, сазлыкларда үсәләр. Тамыр системасы көчсез, тамырлары нәзек, җепсыман. Сабагы 20–300 *см* озынлыкта. Яфраклары чиратлашкан яки җиңсәле, төрле формада (җепсыманнан киң эллипсыманга кадәр); су астындагылары әлпәле, үтә күренмәле, йөзмәләре — тиречел. Чәчәкләре вак, күрексез, цилиндрсыман, башаксыман чәчәк төркемендә, су өслегеннән чыгып тора. Җимеше — чикләвекчек. Июнь–августта чәчәк аталар. Җимешләре июль–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл (тамыр бүлбеләрен бүлеп яки ботакларын тамырлатып) б-н үрчиләр. С.к. б-н су моллюсклары, бөҗәкләр, балыклар туклана, кукаклыклары — уылдык чәчү һәм яшь балыкларга яшеренү урыны. Кайбер төрләре ондатра, кондыз, су кошлары өчен азык булып тора. 8 төре ТРның Казыл китабына кертелгән.

**СУ КОНДЫЗЫ́** (нутрия) (Myocastor coypus), кимерүчеләр отрядының кондызлар семьялыгындагы имезүче җәнлек. Табигый ареалы — Көньяк Американың көньяк өлеше; АКШ, Европа илләре, Кавказ артында, Таҗикстанда климатлаштырылган. Гәүдә озынлыгы 50–60 *см*, койрыгы 30–45 *см*. Авырлыгы 8 *кг* га кадәр. Гәүдәсе тәбәнәк, борыны җәенке, ираннәре кискеч тешләр артында кысылып ябыла, бу үзенчәлек С.к.на су астында да кимерү мөмкинлегә бирә. Арткы аякларының кырыйдагысыннан калган бармаклары яры б-н капланган, колак тишекләре ябылу сәләтенә ия. Йон капламы тупас кыл һәм кыска йомшак йон мамыгыннан тора; төсе җирән соры, аркасы караңгырак төсмердә. Койрыгы һәм аяклары йонсыз диярлек. Туңмый торган сулыкларның сазламыклы ярларында яши. Яшь камыш үсентеләре һәм моллюсклар б-н туклана. Ел әйләнәсе үрчи. Йөклелек чоры 127–133 тәүлек. Берьюлы 2–8 (гадәттә, 5) бала тудыра. Кыйммәтле тиреле җәнлек асраучылык объекты. Читлектә, ярымирекле һәм ирекле режимда тотыла. Стандарт (соры) төстәге тиреләрдән тыш, төсле (мутант) — ак, алсу, перламутр, алтынсу, ак-сыл-сары, көмешсыман, кара һәм катнаш төстәге тиреләр алына. 1960–80 елларда ТРда С.к. Чистай р-нының «Луч», Питрәч р-нының «Кощаково», Бөгелмә р-нының «Восточный» җәнлек с-зларында үрчетелә. Хәзерге вакытта С.к. шәхси хуҗалыкларда асрала.

*Әд.:* Р о м а н о в О.А. Мягкое золото Татарии. К., 1986; А х м е т о в И.З. Нутриеводство. Таш., 1988; Б е р е с т о в В.А. Звероводство. СПб., 2002. *Ә.Х.Фазылҗанов.*

**СУ ЛАЛӘСЕ́**, к. *Төнбоек*.

**СУ РЕСУ́РСЛАРЫ**, кулланырга яраклы сулар. ТРда — елга, күл, сусаклагыч, сазлык, буа, җир асты сулары, туфрак дымы, кар капламы сулары. ТР С.р.ның гомуми күләме (берьюлы куллану запасы) — елга (агым) сулары — 0,26 *км³*, күл — 0,028 *км³*, сусаклагыч (Куйбышев, Түбән Кама, Зәй, Карабаш сусаклагычларының тулы күләме) — 70,31 *км³*, буалар — 3,1 *км³*, актив су алмашы зоналарындагы җир асты сулары — 2,4 *км³*. Берьюлы куллану запасыннан тыш су әйләнеше процессында өзлексез яңартылып торучы С.р. запаслары бар, аларның төп өлешен җир асты, яңгыр һәм кар сулары тудырган елга агымы тәшкил итә. Күпьеллык күзәтүләр буенча ТР терр-ясендә формалашкан су агымының уртача еллык күләме 8,1 *км³* тәшкил итә.

С.р. балансын исәпләү өчен терр-янең су балансы тигезләмәләре системасы кулланыла: $y=y_{ж.а.}+y_{ж.ө.}$; $x=y_{ж.а.}+y_{ж.ө.}+z$; $x=y+z$; биредә: x — явым-төшемнәрнең еллык күләме, y — тулы елга агымы, $y_{ж.а.}$ — җир асты сулары агымы, $y_{ж.ө.}$ — җир өсте сулары агымы, z — парга әйләнү. Бер елга ТРның бөтен терр-ясе өчен уртача x=520 *мм*, y=119 *мм*, $y_{ж.а.}$=34 *мм*, $y_{ж.ө.}$=85 *мм*, z=401 *мм* тәшкил итә.

С.р. ике төрле формада кулланыла: судан файдалану һәм суны куллану. Судан файдалану су объектларыннан суны алмыйча гына бара (гидроэнергетика, су транспорты, балыкчылык, туризм). Суны куллану аны су агымыннан яки җир асты сулары бассейны-

на әйләнеп кайтармаслык итеп, ш.у. сыйфаты үзгәртелгән суны өлешчә яки тулысы б-н су алган урыннан үзгә җиргә кире кайтарырлык итеп алу б-н бәйле.

*Әд.:* Станкевич Е.Ф. Подземные воды Татарии. К., 1967; Ресурсы поверхностных вод СССР. Л., 1971. Т. 12, вып. 1; 1973. Т. 11; Петрова Р.С. Водные ресурсы Татарии и их использование для орошения. К., 1975; Озёра Среднего Поволжья. Л., 1976.

*В.И.Мозжерин.*

**СУ ТАЛПАННАРЫ́** (Hydracarina), суда яшәүче акариформалылар отрядыннан талпаннар семьялыгы төркеме. Күбесенчә төче сулыкларда яшәүче 2000 гә якын төре билгеле. Аз өйрәнелгән төркем, Татарстан терр-ясендә төрләрнең төгәл саны билгеле түгел. Hydrachna, Hygro bates, Piona ыруглары вәкилләре еш очрый. Вак (0,2–7 *мм*) С.т.бөтен, түгәрәк гәүдәле, еш кына ачык төстәге калын япма б-н капланганнар. Икеле 2 пар күзе, йөзү төкчәләре б-н капланган 4 пар аягы бар. Барлык сулык типларында: күл, елга һәм күлләвекләрдә очрыйлар. Актив ерткычлар, вак кыслачыклар һәм бөҗәк личинкаларын юк итәләр. С.т.ның личинкалары суда яшәүче бөҗәкләрдә яки тешсез әкәм-төкәм куышлыгында паразитлык итәләр.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1968. Т. 2.

*В.А.Яковлев, Т.А.Кондратьева.*

**СУ ТАШУ́**, ел саен бер үк фасылда елга суының шактый артуы һәм аның нык күтәрелүе; гадәттә, бу вакытта тугайларның су астында калуы күзәтелә. Уртача поясның тигезлек елгаларындагы кебек үк Татарстан елгаларында да С.т. язын кар эрү б-н бәйле. Респ-каның көньяк өлешендә уртача алганда 28–30 мартта, төньякта — 4–5 апрельдә башлана, тиңдәшле рәвештә 27–28 апрельдә һәм 5–7 майда тәмамлана. Апрельдә ТР терр-ясендә формалашкан ташу агымы уртача айлык агымнан 6–7 тапкыр, кышкы чиллэдәге уртача айлык агымнан 20 тапкырдан артып китә. С.т. чорында кар сулары агымының



Вятка елгасында су ташу.

уртача күләме 5 *км*³ яки гомуми еллык агымның 61,9% ын тәшкил итә. Куйбышев сусаклагычы төзелгәнгә кадәр С.т. вакытында Идел һәм Кама елгаларының түбән агымында су биеклеге 9–10 *м* га күтәрелгән. Уртача зурлыктагы елгаларда (Чишмә, Зәй, Зөя һ.б.) су биеклеге 4–6 *м*, кече елгаларда 2–3 *м* га арта.

**СУ ТРА́НСПОРТЫ**, к. *Елга транспорты.*

**СУ ТУРГАЙЛАРЫ́** (Cinclus), шул ук семьялыктан кошлар ыругы, 5 төре билгеле, Евразия, Төньяк-Көнбатыш Африка, Төньяк Америкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади су тургае (C. cinclus) бар. Сирәк очып керүче кош, Казансу һәм Сумка елгаларының яр буенда очрый. Гәүдәсенең озынлыгы 14–20 *см*, канат җәеме 30 *см*, авырлыгы 50–70 *г*. Кара-коңгырт төстә, муены, түше ак. Каурый капламы бик куе, юешләнми торган. Томшыгы зур түгел, өскә таба бөгелгән. Канатлары кыска, түгәрәкләнгән. Койрыгы туры, кыска. Аяклары көчле, шактый озын. Ерак булмаган араларга түбәннән оча. Яннан керешле шарсыман оясын суга якын җирләрдә: текә ярларда, күпер асларында, ташлар арасында кора. Тимгелле 5 ак йомырка сала. Азык эзләгәндә суга чума һәм су төбендә чабып йөри ала, шундагы вак умырткасызлар б-н туклана. Колак һәм борын тишекләренең су керүдән саклаучы тиречел капкачлары бар.

**СУ «ҮГЕЗЛӘРӘ́»** (Bombina), түгәрәктелләр семьялыгыннан койрыксыз җир-су хайваннары ыругы. 5 төре билгеле, Европада һәм Көнчыгыш Азиядә таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — кызыл корсаклы су «үгезе» (B. bombina) яши. Көннең күп өлешен суда (сазлыкларда, инеш, буаларда) үткәрә, яр буена эңгер-меңгердә генә чыга. Гәүдәсенең озынлыгы 5–6 *см*. Тиресе төерле. Аркасы кара яки яшькелт таплы коңгырт-соры, корсагы зәңгәрсу-кара таплы ачык кызыл-сары яки кызыл төстә. Тешләре фәкать өске казналыкта гына. Теле диск сыман. Күз карасы өчпочмаклы. Йөзү элпәләре алгы очлыгында юк, арткыларында яхшы үсеш алган. Ялкынсыну вакытында С.«ү.»нең тиресе сабын күбеген хәтерләтүче зәһәр лайла бүлеп чыгара, ул аларны ерткычлардан саклый. Яшәвенең 3 нче елында җенси яктан җитлегә. Уылдыгын май уртасында чәчә, ана зат, өлешләп, 20–80 шәр бөртек 300–750 уылдык чәчә. Яшь С.«ү». июль ахыры – август башында күренәләр. Күбесенчә су умырткасызлары, аеруча озынборын личинкалары б-н тукланалар. Коры җирдә, кимерүчеләр ояларында, чокырларда кышлыйлар. Табигатьтә 10 елга кадәр яшиләр. Саклауга мохтаҗ.

**СУ ҮТКӘРГЕЧЛӘ́Р ЧЕЛТӘРЕ́**, кулланучыларга су җибәрү өчен бикләвеч арматура, насос станцияләре һәм су бирү җайланмалары б-н җиһазландырылган үткәргеч торбалар системасы. Су б-н тәэмин итү системасының төп элементы булып тора. С.ү.ч.ндә су чиста су резервларыннан насос станциясе тарафыннан бирелә. С.ү.ч. боҗрасыман, тармаклы һәм катнаш рәвештә була. Боҗра сыман челтәрләр ныклырак булулары б-н аерылып торалар. Үткәргеч торбаларның оптималь диаметрлары су чыгымы күләме буенча билгеләнә. Торак пунктларда С.ү.ч.ндә су басымы 6 атм.дан артырга тиеш түгел. С.ү.ч. тимер-бетон, пластмасса, чуен һәм корыч торбалардан корыла. Металл торбаларның эчке өслеге коррозиядән цементлы яки полимерлы капламлар б-н саклана.

Идел буе Болгар дәүләте терр-ясендә С.ү.ч.нең беренче элементлары Болгар шәһәрендә барлыкка килә. Казанда беренче суүткәргеч 1874 елның 24 октябрендә сафка баса. Шәһәргә су Пановка чишмәләреннән бирелә. Су бирүнең уртача күләме тәүлеккә 3000 *м*³ тәшкил итә, 25 *км* озынлыктагы суүткәргеч магистральләр файдаланыла. 2000 елга су бирүнең уртача тәүлеклек күләме 100 тапкырдан күбрәккә, Казанның һәр кешесенең су куллануы 125 тапкыр диярлек арта. Халыкның һәм сәнәгать пр-тиеләренең суны күп куллануы сәбәпле, су бирүне артезиан скважиналары бораулау хисабына арттырырга карар кылына. 1892–98 дә Әки авылында 4 артезиан скважинасы, 1911 дә Царицыно авылы янында 1 скважина (Азино сужыйгычы) бораулана. 1913 тә С.ү.ч. озынлыгы 47 *км* тәшкил итә, тәүлеккә 4400 *м*³ чишмә һәм артезиан суы бирелә. 2015 елга ТРда С.ү.ч.нең гомуми озынлыгы 13000 *км* дан арта, ш.и. Казанда 1500 *км* чамасы тәшкил итә. Респ-каның шәһәрләрендә суүткәргечләр б-н торак фондының 91,2% ы, авыл җирендә 44,3% ы җиһазландырылган.

*Әд.:* Николадзе Г.И., Сомов М.А. Водоснабжение. М., 1995; Казанский водоканал // Бизнес в Татарстане. 1997. № 2; Ерунов Б.Ю. Юбилей творцов чистой воды: Казанскому водопроводу 120 лет // Казанские ведомости. 1994. 25 окт.; Гарбузова Н. Программа «Питьевая вода РТ» под угрозой срыва // Время и деньги. 2000. 18 февр.

*Р.С.Сафин.*

**СУ ХУҖАЛЫГЫ́**, халык хуҗалыгы тармагы, су байлыгыннан комплекслы файдалануны планлаштыру, исәпкә алу, өйрәнү, җир өстендәге һәм җир астындагы суларны пычранудан саклау, суны кулланыласы урынга китерү, суларга зарарлы тәэсирләрне бетерү һәм кисәтү б-н шөгыльләнә. Төп бурычы — халык хуҗалыгының барлык тармакларын су б-н тәэмин итү. С.х. ш.у. елгалар, сусаклагычлар һәм сулыкларны суднолар йөреше, гидроэнергетика, балык үрчетү һ.б. ихтыяҗлар өчен файдалану, җирләрне су басудан саклау проблемаларын хәл итә. Халык хуҗалыгы тармаклары су байлыкларыннан файдалану үзенчәлеге буенча суны кулланучыларга (сәнәгать, а.х., коммуналь хуҗалык) һәм судан файдаланучыларга бүленә, болары суның үзеннән түгел, ә судан алына торган энергия яисә су тирәлегеннән (гидроэнергетика, су транспорты, балыкчылык һ.б.) файдалана. Су байлыклары чыганагы — елгалардагы һәм башка сулыклардагы элекке хәленә кайта торган су запаслары. Татарстанда — болар Идел һәм Кама елгалары бассейннары, аларның тармакланган кушылдык челтәре, грунт һәм кар сулары. Татарстанның иң зур сулыгы — Урта Идел һәм Түбән Кама сусаклагычы, алар суднолар йөреше, ш.у. сәнәгать, а.х., халык ихтыяҗы өчен су чыганагы сыйфатында файдаланыла. Күлләр челтәре һәм ясалма сулыклар ТРда аз үсеш алган. Су байлыкларыннан файдалану су хуҗалыгы балансы нигезендә, ягъни суга ихтыяҗ б-н су байлыкларының күләме һәм сыйфаты чагыштырмасында гамәлгә ашырыла. Үсеш перспективаларын исәпкә алып, халык хуҗалыгы тармакларының һәм халыкның суга ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен, ш.у. сәнәгать һәм көнкүреш агынтылары б-н пычранудан саклау һәм суларга зарарлы тәэсирләр б-н көрәш өчен елга, сусаклагыч, күл һ.б. сулыкларны комплекслы файдалану һәм саклау уздырыла. Татарстанда бу эшне Табигый бай-

лыклар һәм экология министрлыгы, Урта Идел бассейны су хуҗалыгы идарәсе, Су җыю корылмалары идарәсе, Водоканал, шәһәр су чистарту корылмалары, насос станцияләре башкара.

*В.А.Наумов.*

**СУ ЧАЯННАРЫ́** (Nepidae), кандалалар семьялыгы. Дөнья фаунасында 150 гә якын; Татарстан терр-ясендә 2 төре билгеле: нык су-зынкы нәзек гәүдәле чыбыксыман ранатра (Ranatra linearis) һәм озынча түгәрәк гәүдәле гади су чаяны (Nepa cinerea). Агымсыз һәм акрын агымлы сулыкларда яшиләр. Су төбендә яки су үсемлекләре буйлап хәрәкәтләнәләр, начар йөзәләр, алгы аяклары эләктереп алырга җайлашкан. Гәүдәсенең очында атм. һавасын сулау өчен озын сулыш көпшәсе бар. Суда кышлыйлар. Ерткычлар. Татарстанда Идел-Кама саклаулыгының Раифа урманчылыгы күлләрендә, Куйбышев сусаклагычы култыкларында, Идел һәм Кама елгаларының тугай күлләрендә һәм култыкларында очрый. Ике төре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Определитель насекомых Европейской части СССР. М.–Л., 1965. Т. 2; Красная книга РТ. К., 1995.

*С.М.Шәфигуллина.*

**СУ ЧӘЧӘГЕ́** (Nymphoides), кондыз үләнчәләр семьялыгыннан күпьеллык су үсемлекләре ыругы. 20 гә якын төре билгеле, Европа һәм Азиядә таралган. ТР терр-ясендә бер төре — калкан яфраклы С.ч. (N. peltata) Идел елгасының элеккеге тугае сулыгында (Яшел Үзән р-ны, Обсерватория станциясе) үсә. Үсү тирәлегенең су астында калуы сәбәпле, С.ч. юкка чыга. 90–150 *см* биеклектәге үсемлек, буынтыклы шуышма тамырчалы, түгәрәк яфраклары озын сапларда, эре сары чәчәкләре су өстендә йөзеп йөрүче чатыр чәчәк төркеменә җыйналган. Яфракларның өске ягы ялтыравыклы. Үсемлекнең суга күмелгән өлешләре — кара төстәге төерле. Июль–сентябрьдә чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Су кошлары, ондатра һәм нутрия өчен азык. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**СУ-ЕЛГА́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 20 *км* көнбатыштарак, Омар елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 148 кеше (татарлар) яши. Урман хуҗалыгы, такта яру з-ды. 1924 тә нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Мамадыш кантоны Мамадыш волостенда. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 242, 1949 да — 175, 1958 дә — 162, 1970 тә — 214, 1979 да — 164, 1989 да — 159, 2002 дә — 154 кеше.

**СУАЛЧАННА́Р**, сузынкы гәүдәле түбән төзелешле ике яклы — симметрияле умырткасыз хайваннарның җыелма төркеме. Гәүдәсен кыскартырга һәм шуның ярдәмендә хәрәкәтләнергә сәләтле тире-мускул капчыгы бар. 20 меңгә якын төре билгеле. ТРда С.ның өч тибы киң таралган: *яссы суалчаннар*, йомры (к. *Нематодалар*) һәм *бөҗралы суалчаннар*. Яссы суалчаннардан барлык җирдә очрый торган ирекле яшәүче керфекле *планариялар* — ерткычлар, иң гади төзелешлеләр, вак кысласыманнар, бөҗәк личинкалары б-н туена. Имгечләр һәм *тасма суалчаннар* (*солитёрлар, каешчалар*, тасмачалар, *эхинококк*) — хайван һәм кешеләр паразиты. Сулыкларда йомры суалчаннардан *чәчсуалчаннар*, *бөтерелчек суалчаннар* яши, алар исә балык маймычлары б-н туклана. *Ыргакбашлар*, нигездә, — кысласыманнар һәм бөҗәкләрдә, *аскаридалар*, *бабасырлар* кыргый һәм йорт хайваннары, кеше эчәклегендә паразитлык итәләр. Бөҗралы *аз төкле суалчаннар* туфракта һәм сулыкларда яшиләр. Куйбышев сусаклагычы төзелгәннән соң, Каспий диңгезеннән күп кенә төкле суалчаннар керә, алар исә төче суда яшәргә яраклашалар. Яңгыр суалчаннары һәм быргычыклар органик калдыкларның таркалу процессын тизләтеп файда китерәләр. Сөлекләр күп кенә хайваннар өчен азык булып торалар, кайберләре кан суырып балыкларга, кошларга, имезүчеләргә һәм кешеләргә зыян китерәләр.

*Р.М.Сабиров.*

**СУА́Р**, Идел буе Болгар дәүләтендәге урта гасырлар (9 — 14 йөзләр) шәһәре. Язма чыганакларда 10 йөздән башлап искә алына. 948–75 елларда *Суар бәклегенең* башкаласы, акча сугу урыны (10 йөз). Соңрак Идел буе Болгар дәүләте составына керә, дәүләтнең эре сәяси, икътисади һәм сәүдә үзәгенә әверелә. Шәһәр яны урлар б-н әйләндереп алына. Халкы игенчелек, терлекчелек, һөнәрчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 1236 да Бату хан гаскәрләре тарафыннан басып алына. Фаразлар буенча, *Болгар бәклеге* составында гади шәһәр булып кала. 14 йөз ахырына элеккеге сәяси һәм икътисади әһәмиятен югалта, 15 йөздә яшәүдән туктый. Шәһәрнең археол. калдыкларын Үтәк елгасының (Идел кушылдыгы) югары агымы буендагы хәзерге Спас р-ны Кузнечиха авылы тирәсендәге *Суар шәһәрлеге* б-н бәйләп карыйлар.

*Әд.:* С м и р н о в А.П. Волжские булгары. М., 1951; Х у з и н Ф.Ш. Булгарский город в X — начале XIII вв. К., 2001.

*И.Л.Измайлов.*

**СУА́Р БӘКЛЕГЕ́**, Урта Идел буендагы болгар бәклеге. 940 елларда суарлар б-н җирле төрки-фин-угор кабиләләренең берләшүе нәтиҗәсендә барлыкка килә. Башкаласы — *Суар* шәһәре. Суар бәклеге идарәчеләреннән Габдулла бине Микаил, Талиб бине Әхмәд, Мөэмин бине Әхмәд мәгълүм. 975 тә Болгар бәклеге б-н берләшә. Идел буе Болгар дәүләтен монгол гаскәрләре яулап алгач, *Болгар бәклеге* составында була.

*Әд.:* С м и р н о в А.П. Волжские булгары. М., 1951; Ф а х р у т д и н о в Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984; И з м а й л о в И.Л. Образование Булгарского государства // История татар с древнейших времён. Т. 2. Волжская Булгария и Великая степь. К., 2006.

*И.Л.Измайлов.*

**СУА́Р ШӘҺӘРЛЕГЕ́**, археол. истәлек; Үтәк елгасының (Идел елгасы кушылдыгы) сул ярындагы 10–14 йөзләр болгар торулыгы, Спас р-ны Кузнечиха авылыннан 4,5 *км* көнбатыштарак урнашкан. Беренче тапкыр 1893 елда Г.Н.Әхмәров тарафыннан тикшерелә, 1933–37 дә А.П.Смирнов, 1974–75 тә Т.А.Хлебникова, 1990–94 тә Ф.Ш.Хуҗин, Р.Ф.Шәрифуллин һ.б. тарафыннан өйрәнелә. С.ш.нең гомуми мәйданы 90 *га* дан артык, ш.и. 64 *га* — эчке шәһәр терр-ясе. Планда дүрт почмаклы формадагы шәһәрлек озынлыгы 4,5 *км* га сузылган биек урлар һәм тирән чокырлар б-н әйләндереп алынган була. С.ш. янында зур мәйданлы Покровское, 1 нче һәм 2 нче Татгородокское авыллыклары ачыклана. Шәһәрлек терр-ясендә урлар өстендә бура-келәт рәвешендәге агач саклану корылмалары, монументаль кирпеч ныгытмалар («Суар сарае») калдыклары, балчык сылап эшләнгән бүрәнә торак һәм хуҗалык корылмалары, 2 каберлектә мөселман каберләре һ.б. сакланып калган. Кайбер галимнәр С.ш.н *Суар* шәһәре б-н бәйләп карыйлар. *Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы* составына керә.

*Әд.:* С м и р н о в А.П. Сувар: Итоги раскопок 1933–1937 гг. // Тр. Гос. ист. музея. 1941. Вып. 16; Х у з и н Ф.Ш., Ш а р и ф у л л и н Р.Ф. Город Сувар: Некоторые итоги и задачи археологического исследования // Проблемы древней и средневековой археологии Волго-Камья. К., 1999.

*Ф.Ш.Хуҗин.*

**СУАРЛА́Р**, к. *Савирлар*.

**СУБА́ЕВ** Бакый Мөхәммәтгалим улы (1864, Казан — 1917 дән соң), Казан сәүдәгәре, эшмәкәре. 1888 елда сәүдәгәрләр И.М.Борнаев, М.Ә.Сәйдәшев б-н бергә мех һ.б. товарлар б-н сату итүче «Субаев Б., Борнаев И. һәм Сәйдәшев М.» сәүдә йортын оештыра. 1894 тә пр-тие устав капиталы 500 мең тәшкил иткән «Ә.Я.Сәйдәшев уллары б-н һәм Б.Субаев» пай ширкәте итеп үзгәртелә. Ул пыяла, мех әйберләре, ш.у. чәй, шикәр җитештерү һәм сату б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында ширкәтнең эшләре начар бара, 1904 тә С. сәүдәгәрләр катлавыннан чыгарыла.

*Р.Р.Салихов.*

**СУБА́ЕВ** Нияз Габдулла улы (30.5.1925, Казан — 10.10.1998, шунда ук), тарихчы, тарих фән. д-ры (1990). 1941–47 елларда Казан авиация з-дында термист-рихтовщик. Казан ун-тын тәмамлый (1952). ТАССР Дәүләт музеенда (1955–57), КПССның Татарстан өлкә ком-ты каршындагы КПСС тарихы ин-тында (1957–59), КПССның Татарстан өлкә ком-ты архивында (1959–65), Казан мед. ин-тында (1965–92), ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1992–93) эшли. Хезмәтләре Гражданнар сугышы тарихына, 1920 елларда СССР һәм чит ил эшчеләре арасындагы халыкара мөнәсәбәтләрнең үсеш мәсьәләләренә карый. «Идел буенда гражданнар сугышы, 1918–20» («Гражданская война в Поволжье, 1918–20», 1974) хезмәтен нәшер итүдә, «Совет власте өчен» («За власть Советов», 1960), «Чит илләр хәрби интервенциясе һәм Гражданнар сугышы елларында Татарстан большевиклары (1918, август – 1920 , декабрь)» («Большевики Татарии в годы иностранной военной интервенции и Гражданской войны (август 1918 – декабрь 1920)», 1961), «Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан (1941–1945 еллар)» («Татария в период Великой Отечественной войны (1941–1945 гг.)», 1963) документлар җыентыкларын төзүдә катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.



И.П. Субботин.

Х е з м.: Родники солидарности. К., 1971; Орган турецких интернационалистов «Ени дунья» как исторический источник // Народы Азии и Африки. 1975. № 2; Польский журнал в Татарии как источник изучения культурной жизни польского населения // Советское славяноведение. 1989. № 2.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**СУБА́ЕВ** Флюр Йосыф улы (20.7.1930, БАССРның Бәләбәй кантоны Кыскаелга а. — 28.7.2000, Уфа ш.), генерал-майор (1980). Бәләбәй пед. уч-щесен (1948), Алма-Ата хәрби чик сакчылары уч-щесен (1953), Бөтенсоюз читтән торып уку хокук ин-тын (Хабаровск ш., 1965), СССР Дәүләт иминлеге ком-ты органнарының Югары чик буе командирлары курсларын һәм Югары мәктәп каршындагы җитәкчеләр составы ф-тын тәмамлый (Хабаровск ш., 1985). 1948–50 елларда Кыскаелга авылында тарих укытучысы булып эшли. 1950 дән Совет Армиясе сафларында. 1953–76 да Ерак Көнчыгыш чик буе округында: 1953–60 та 55 нче Кызыл Байраклы чик буе заставасы башлыгы урынбасары, башлыгы, 1962–76 да Благовещенск чик буе отряды башлыгы. 1977–84 тә Байкал аръягы Кызыл Байраклы чик буе округы башлыгы урынбасары һәм Хәрби совет әгъзасы. 1981–84, 1986–90 да Кавказ арты чик буе округы командиры урынбасары һәм Хәрби совет әгъзасы. 1984–86 да Әфганстан Респ-касында хезмәт итә. 1990 да Тбилисидан Уфага күченә. 1992 дән отставкада. РФнең Башкортстан Респ-касы буенча Федераль Иминлек советы идарәсендә, Башкортстан «Иминлек һәм хокук тәртибе» хокук саклау органнарының социаль яклау ассоциациясе рәисе булып эшли, Чик буенда махсус техника урнаштыру һәм кулланылышка кертүдә катнашканы өчен СССР Дәүләт бүләге бирелә (1987). Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Уфада С. яшәгән йортка мемориаль такта куела.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СУБА́Ш** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 25 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Нырсы елгасы буенда. 2010 елда 218 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Дүртөйле Субаш исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, итек тегү һәм киез итек-киез җитештерү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Изге Гурий борадәрлеге (1872 дә ачыла, 1910 да земство мәктәбе итеп үзгәртелә), кыз балаларны укырга-язарга өйрәтү (1911 дән) мәктәпләре, су һәм җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1145,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Шомырбаш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 100 ир-ат; 1859 да — 373, 1897 дә — 720, 1908 дә — 873, 1920 дә — 935, 1926 да — 720, 1938 дә — 649, 1949 да — 606, 1970 тә — 492, 1979 да — 384, 1989 да — 285, 2002 дә — 209 кеше.

**СУБА́Ш АТЫ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Аты елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 206 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына; 1960 елларга кадәр Кече Аты буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, киндер туку б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 2 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1528,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Яңа Кишет волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 111 ир-ат; 1859 да — 531, 1897 дә — 911, 1908 дә — 1004, 1920 дә — 863, 1926 да — 992, 1938 дә — 1004, 1949 да — 744, 1958 дә — 534, 1970 тә — 505, 1979 да — 377, 1989 да — 255, 2002 дә — 245 кеше.

**СУББО́ТИН** Иван Павлович (14.9.1922, Лаеш кантоны Корноухово а. — 30.12.1983, хәзер Мари Респ-касының Волжск ш.), Дан орденының тулы кавалеры (16.1.1944, 9.5.1944, 24.3.1945), гв. старшинасы. Колхозда эшли. 1941 елның ноябреннән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында: 210 нчы гв. укчы полкында пулемётчы, отделение командиры (6 нчы армиянең 71 нче гв. укчы дивизиясе). Воронеж, 2 нче һәм 1 нче Балтыйк буе фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Витебск-Орша, Полоцк һәм Мемель (барысы да — 1944) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 5 гыйнварында Новосокольники шәһәреннән (Псков өлкәсе) көньяктарак сугышта батырлык күрсәтә: пулемёттан атып, дошманның танкка каршы орудие расчётын сафтан чыгара, шуның б-н совет укчы подразделениеләренең уңышлы хәрәкәтенә ярдәм итә; 1944 нең 2–12 мартында, шәһәр тибындагы Идрица посёлогыннан көньяк-көнчыгыштарак дошман контрһөҗүмен кире кайтарганда, дошманның дистәдән артык солдатын юк итә, яралана, әмма сафта кала; 1944 нең июнендә шәһәр тибындагы Бешенковичи посёлогы (Витебск өлкәсе) янындагы сугышта разведчиклар төркеме б-н дошманның 4 понтон күперен батыра, көймәсен кулга төшереп, Көнбатыш Двина елгасын кичеп чыга һәм дошман траншеясына бәреп керә, ике немец солдатын әсир алып, аларны полк штабына кайтарып тапшыра. 1945 тә демобилизацияләнгәннән соң, Волжскида яши, мебель ф-касында эшли. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СУББО́ТИН** Михаил Фёдорович (1835, ноябрь, С.-Петербург — 8.4.1893, Мәскәү), терапевт, медицина д-ры (1863). Мед.-хирургия академиясен (С.-Петербург) тәмамлаганнан соң (1860), хәрби медицина хезмәтендә (1864 елга кадәр). 1865–67 дә Халык мәгарифе министрлыгында. 1867–86 да Казан ун-тында, гомуми патология (1872 дән аерым патология һәм терапия) кафедрасында, бер үк вакытта, 1877 дән, госпиталь терапиясе клиникасында, проф. (1868). Хезмәтләре уремия вакытында кан патологиясен, химик ярсыткычлар б-н тәэсир иткәндә нервлар ярсынуын, сидек эшләп чыгаруда бөер тукымасының ролен өйрәнүгә карый.

Х е з м.: О физиологическом действии пикротоксина // Военно-мед. журн. 1864. Ч. 91; О влиянии пищи на количественный состав молока // Военно-мед. журн. 1867. Ч. 98.

**СУББО́ТИН** Серафим Иванович (3.5.1906, Казан — 16.11.1976, Киев), геофизик, физика-матем. фән. д-ры (1955), Украина ССР ФА академигы (1961; 1957 дән мөхбир әгъза), Украина ССРның атказ. фән. эшлеклесе (1966). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1931), Кавказ арты геол. идарәсендә (Тбилиси) эшли. 1938 елдан Ленинград гамәли геофизика ин-тында, 1939 дан Украина геол. идарәсендә, 1940 тан Дәүләт геофизика трестының Урта Идел буе бүлегендә (Куйбышев ш.). 1944 тән Украина ССР ФАндә: Геол. фәннәре ин-тында, 1950 дән Файдалы казылмалар геологиясе ин-тында, 1960 тан Геофизика ин-ты директоры. Хезмәтләре теоретик һәм гамәли геофизикага, тектогенез теориясенә карый. С. гравиметрик алымнар б-н Татарстан терр-ясендә нефть чыганаклары ачыкланган яңа локаль структуралар таба. Украина ССР Дәүләт (1972), СССР ФАнең В.И.Вернадский исем. (1976) бүләкләре лауреаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Процессы в верхней мантии Земли и связь с ними строения земной коры. Киев, 1964; Мантия Земли и тектогенез. Киев, 1968.

**СУБУЯ́Р** (Hydrocharis), субуярчалар семьялыгыннан күпьеллык су үсемлекләре ыругы. 6 төре билгеле, Европа, Азия, Төньяк Африка, Австралиядә таралган. ТР терр-ясендә бер төре — гади С. яки бака түшәге (H. morsus-ranae) бар. Барлык районнарда очрый. Агымлы һәм әкрен агымлы сулыкларда үсә. Ботаклары 15–30 *см* озынлыкта. Сабагы җепсыман. Яфраклары бөтен, сабакчалы, яфрак таралгысына җыйналган. Чәчәкләре бер җенесле, эре, ак төстә, озын чәчәк сапларында. Җимеше — җиләксыман. Июль-

дә чәчәк ата. Горизонталь үскән бәбәкләр ярдәмендә үрчи, алар очында яшь организмнар барлыкка килә. Бөре рәвешендә кышлый, көзен исә алар төпкә төшә, ә язын су өслегенә чыгалар. Халык медицинасында яфрак төнәтмәсе бәвел кудыру чарасы. Аквариум үсемлеге буларак файдаланыла.



Гади субуяр.

**«СУВА́Р»**, иҗтимагый-сәяси атналык газета. Оештыручылары — ТР МК, Казан шәһәре хакимияте башлыгының коммуналь милек б-н идарә итү ком-ты, газета редакциясенең хезмәт коллективы. 1993 елның августыннан Казанда чуаш телендә нәшер ителә. Нашире — «Татмедиа» ААҖ. Төрле еллардагы баш мөхәррирләре — В.Данилов, А.К.Иванов, К.А.Малышев. Татарстан һәм Россиянең башка төбәкләрендәге чуаш диаспорасының соц.-сәяси, икътисади һәм мәдәни тормышы яктыртыла, төрледән-төрле мавыктыргыч һәм танып белү материаллары басыла. 1995 тән кушымтасы «*Шурампус*» ж-лы чыгарыла.

**СУВЕРЕНИТЕ́Т** (нем. Souveranitat, фр. souveraineté — югары хакимият), дәүләтнең эчке тормышын оештыру, милли үсеш һәм тышкы багланышлар мәсьәләләрен хәл итүдәге мөстәкыйльлеге. Татарстан Респ-касы чикләнгән С.тан файдалана, аның законнары Россия Федерациясе хөкүмәте б-н килешү нигезендә аның үзе тарафыннан РФнә тапшырылган хокук кысаларыннан читтә генә өстенлек итә. С. төшенчәсе Татарстанның һәм бу хокукларны гамәлгә ашыруы Окт. рев-циясе җиңгәннән соң Россия Федерациясе оешу процессында башлангыч ала.

1917 елның 16 ноябрендә «Правда» г-тасында «Россия халыкларының хокуклар Декларациясе» басылып чыга, анда халыкларның тигезлеге һәм суверенлыгы, аларның бүленеп чыгып мөстәкыйль дәүләтләр төзү дәрәҗәсенә кадәр ирекле үзбилгеләнү хокукы игълан ителә. 1918 нең 31 гыйнварында Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советларының 3 нче Бөтенроссия съездында «Эшче һәм изелгән халыкларның хокуклар Декларациясе» кабул ителә. Аның 1 нче бүлегенең 2 нче маддәсендә: «Россия Совет Республикасы ирекле милләтләрнең ирекле берлеге нигезендә совет милли республикаларының федерациясе буларак оештырыла», — диелә. Бу Декларация, мөһим конституцион акт буларак, 1918 нең 10 июлендә Советларның 5 нче Бөтенроссия съездында кабул ителгән РСФСР Конституциясенә беренче бүлек итеп кертелә. Декларациянең соңгы пунктында «өлкә совет республикалары» «федераль Хөкүмәттә һәм башка федераль учреждениеләрдә» «катнашырга телиләрме һәм ни рәвешле» икәнлеген «вәкаләтле совет съездында» үзләре хәл итәләр, дип билгеләнә. Шул рәвешле асимметрик федерациягә нигез салына.

1918 дә — 1920 еллар башында Россиядә Гражданнар сугышы чорында РСФСР составына кергән автономияле респ-калар формалашу процессы бара.

СССР төзелү мәсьәләләрен хәл иткәндә, татар сәясәт һәм дәүләт эшлеклеләре (мәс., М.Х.Солтангалиев, Г.Г.Мансуров, К.Г.Мохтаров һ.б.) автономияле респ-каларга СССР составына турыдан-туры керү хокукы бирү идеясе б-н чыгыш ясыйлар, Россия халыкларын төрле дәрәҗәләргә бүлүгә каршы чыгалар. Әмма бу идея И.В.Сталин тарафыннан кире кагыла, аның тарафдарлары «милли тайпылыш»та гаепләнә һәм репрессияләргә дучар ителә (к. «*Солтангалиевчелек*»).

Бөтенроссия ҮБК һәм РСФСР ХКСның 1920 ел 27 май Декреты б-н Автономияле Татарстан Совет Социалистик Республикасы (ТАССР) төзелә. Аның үз конституциясе, законнар чыгару һәм башкарма хакимият органнары, законнар чыгару хокукы, югары мәхкәмә органнары, терр-ясенең кагылгысызлыгы, башкаласы һ.б. дәүләтчелек атрибутлары раслана. Әмма андый «үзбилгеләнү» тулы булмый, ул татар халкының тизләтелгән социаль-икътисади һәм мәдәни алгарыш мәнфәгатьләренә җавап бирми.

1930 елларда, СССРның яңа Конституциясен тикшергәндә, Татарстан АССРын союздаш респ-ка итеп үзгәртү мәсьәләсе кабат көн тәртибенә куела, ләкин ул ил җитәкчелегендә хуплау тапмый. Татарстанның, СССРның башка автономияле берәмлекләренең статусы хакындагы мәсьәләләрне хәл итүдә бердәмлек булмау сәбәпле, оештырылганнан соң 17 ел дәвамында респ-каның үз Конституциясе булмый. Ул 1937 дә генә кабул ителә; Конституциянең үзенчәлеге шуннан гыйбарәт: анда формаль рәвештә автономия хакында сүз бара, әмма, асылда, автономия гамәлгә керми. 1980 еллар ахырында, илдә үзгәртеп корулар башлангач, совет хакимиятенең беренче елларында кабул ителгән төп конституцион документлар кабат актуальләшә.

1990 ның 30 августында ТАССР ЮСы респ-каны суверен Татарстан Совет Социалистик Респ-касы (ТССР) дип белдергән «Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларациясе»н кабул итә. Декларациядә РСФСР һәм ТССР арасындагы мөнәсәбәтләрнең шартнамәләр башлангычында төзелергә тиешлеге күрсәтелә. Татарстан терр-ясендәге җир, җир асты һәм табигый байлыклар һ.б. ресурслар фәкать респ-ка халкының милке санала, нинди милләттән, социаль катлаудан булуларына, нинди дин, сәяси юнәлеш тотуларына һ.б. аерымлыкларына карамастан, респ-каның барлык гражданнарының тигез хокуклары гарантияләнә, дәүләт телләре сыйфатында татар һәм рус телләренең тигез хокукта файдаланылуы, башка телләрнең саклануы һәм үсеше тәэмин ителәчәк дип игълан ителә. Декларациянең әзерләнүче Союз шартнамәсен респ-ка имзалавы өчен хокукый нигез булачагы күздә тотыла. Әмма Татарстан АССРның союздаш респ-кага әверелү процессы СССР таркалу сәбәпле өзелә. Әлеге вакыйгалардан соң булган сөйләшүләр нәтиҗәсендә 1991 нең 15 августында РСФСР һәм ТССР арасында якларның «мөнәсәбәтләрне җайга салуның шартнамәле формаларын файдалануга йөз тотуга» ниятләре теркәлгән, БДБнең «башка республикаларының мәнфәгатьләрен кыерсытмаган өстенлекле мәнфәгатьләре искә алынган» беркетмә имзалана. Бу иң яңа тарихта Мәскәү һәм Казан арасында кул куелган беренче документ була. 1992 нең 22 гыйнварында РСФСР һәм ТССР хөкүмәтләре икътисади хезмәттәшлек турындагы килешүне имзалыйлар. 1992 нең 7 февралендә ТССР ЮСы «ТССРның исеме үзгәрү турында» Законын кабул итә, респ-ка Татарстан Респ-касы дип атала башлый. 1992 нең 21 мартында Татарстанда *референдум* уздырыла, аның нәтиҗәләре ТРның суверен демократик дәүләт булуын раслый (сайлаучыларның 61,4% ы яклап тавыш бирә). Респ-каның яңа статусы 1992 нең 6 ноябрендә кабул ителгән *Татарстан Республикасы Конституциясендә* беркетелә, 1994 нең 15 февралендә РФ Президенты Б.Н.Ельцин, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе В.С.Черномырдин, Татарстан Респ-касы Президенты М.Ш.Шәймиев һәм Татарстан Респ-касы Премьер-министры М.Г.Сабиров тарафыннан Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы арасында «*Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында*» Шартнамәгә кул куела. Россиягә — 17, Татарстанга 15 вәкаләт беркетелә, уртак карамакка 23 вәкаләт билгеләнә. Шартнамә нигезендә РФ һәм ТР хөкүмәтләре арасындагы 12 килешү (хәрби төзелеш, хәрби сәнәгать комплексы, бюджет, таможня, тышкы икътисади эшчәнлек турында һ.б.) имзалана, шул рәвешчә Шартнамәне гамәлгә ашыру механизмы булдырыла. Шартнамә РФне федератив дәүләт буларак саклауда һәм ныгытуда мөһим роль уйный, ТРда иҗтимагый-сәяси вазгыятьне яхшырту өчен шартлар тудыра, респ-каның яңа икътисади чынбарлыкка яраклашуына, Татарстан халыкларының милли мәдәниятләре яңарышы һәм алга таба үсеше буенча киң колачлы планнарның гамәлгә ашырыла башлавына ярдәм итә.

Төрле иҗтимагый-сәяси факторлар йогынтысында федератив мөнәсәбәтләр һәм «С.» төшенчәсенең эчтәлеге билгеле бер үзгәрешләр кичерә. Конституцион төрдәге тәкъдимнәр әзерләү, теркәү буенча эш алып бару өчен, ТР Дәүләт Советының 2001 ел 20 сентябрь карары б-н ТРда Конституция комиссиясе (рәисе М.Ш.Шәймиев) төзелә. Аның тәкъдимнәре ТР Дәүләт Советы тарафыннан карала һәм ТРның 2002 нең 19 апрелендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» законы б-н раслана. Нәтиҗәдә, ТР Конституциясе тексты РФнең 1993 елгы Конституциясе б-н тәңгәлләштерелә. ТР Конституциясенең яңа редакциясендә респ-каның конституцион строе нигезләре билгеләнгән 1 нче маддә барлыкка килә. Ан-

да ТРның статусы һәм аның терр-ясенең чикләре ТР һәм РФнең үзара килешүеннән башка үзгәртелә алмый дип күрсәтелә. 4 нче маддәнең 3 нче өлешендә каралганча, «...федераль закон һәм Татарстан Республикасы карамагындагы эшләр буенча Татарстан Республикасының норматив хокукый акты арасында каршылык туган очракта мәсьәлә Татарстан Республикасының норматив хокукый акты нигезендә хәл ителә». 2007 нең 26 июнендә РФ Президенты В.В.Путин һәм ТР Президенты М.Ш.Шәймиев тарафыннан яңа «Эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында...» Шартнамәгә (2007 нең 24 июлендә РФнең Федераль законы сыйфатында раслана) кул куела. Анда Шартнамәне төзегәндә яклар Татарстанның тарихи, мәдәни һ.б. үзенчәлекләреннән чыгып эш итәләр, ТРның 1992 нең 21 мартында уздырылган референдумы нигезендә 1994 нең 15 февралендә төзелгән Шартнамәне куллану тәҗрибәсен исәпкә алалар, диелә. Шартнамәдә ТР Россия Федерациясе субъекты булып тора, РФ һәм аның субъектлары карамагындагы эшләрдән һәм вәкаләтләрдән тыш, тулы дәүләт хакимиятенә ия дип күрсәтелә. Татарстан терр-ясендәге җир, җир асты, су, урман һ.б. табигый ресурсларны файдалану һәм саклау аның күпмилләтле халкының тормышы һәм эшчәнлеге нигезен тәшкил итүен исәпкә алып, яклар респ-каның икътисади, экологик, мәдәни һ.б. үзенчәлекләре б-н бәйле мәсьәләләрне бергәләп хәл итү турында килешенәләр. Күрсәтелгән проблемалар буенча РФ хөкүмәте һәм ТР Дәүләт Советы РФ Федераль Җыенының Дәүләт Думасы каравына закон проектлары кертәләр. Үз вәкаләтләре кысаларында Татарстан чит дәүләтләр субъектлары һәм адм.-терр. берәмлекләре б-н халыкара һәм тышкы икътисади бәйләнешләр булдыра, халыкара оешмалар органнары эшчәнлегендә катнаша, ш.у. халыкара һәм тышкы икътисади бәйләнешләрне гамәлгә ашыру буенча килешүләр төзи (РФнең Тышкы эшләр министрлыгы б-н килешенеп), ТРдан читтә яшәүче татар халкына милли үзенчәлекләрне, мәдәниятне, телне саклау һәм үстерү буенча дәүләт ярдәме күрсәтә (РФ хөкүмәте б-н килешенеп).

ТР дәүләт хакимияте органнарының РФ дәүләт хакимияте федераль органнары, РФ субъектлары, ш.у. чит дәүләтләрнең дәүләт учреждениеләре, оешмалары, сәнәгать һ.б. компанияләре б-н үзара эшчәнлеген тәэмин итү өчен, ТР вәкаләтле, даими, сәүдә-икътисади вәкиллекләр, халыкара оешмалар каршында даими вәкиллекләр булдыра (к. *Татарстан Республикасының вәкиллекләре*).

Чыг.: Конституция (Основной Закон) Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. К., 1937; Образование Татарской АССР: Сб. док. и материалов. К., 1963; Конституция (Основной Закон) Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. К., 1978; Суверенный Татарстан: Документы. Материалы. Хроника / Сост. Д.М.Исхаков. М., 1998; Конституция Республики Татарстан. К., 2002.

*Әд.:* Хафизов Ш.Ш. Развитие советской государственности татарского народа. К., 1966; Ягудин Ш.Ш. Политико-правовой статус автономной республики в советской федерации // Советское государство и право. 1990. № 3; Железнов Б.Л. Правовой статус Республики Татарстан. К., 1996; Договор Российской Федерации и Республики Татарстан: Пять лет развития. К., 1999; Тагиров И.Р. История государственности Татарстана. XX век. К., 2005; Республика Татарстан: Новейшая история. События. Комментарии. Оценки. / Авторы-составители Ф.Х.Мухаметшин, Л.В.Агеева. В 3-х томах, К., 2000–2009; Шаймиев М.Ш. Новая страница в истории Татарстана // Республика Татарстан. 2010. 26 авг.

*И.Р.Таһиров, Г.С.Сабирҗанов.*

**«СУВЕРЕНИТЕ́Т»** (Татарстан суверенлыгын яклау һәм гамәлгә ашыру ком-ты), иҗтимагый-сәяси оешма. Бөтентатар иҗтимагый үзәге (БТИҮ) активистлары тарафыннан оеша; 1990 елның мартында БТИҮ пленумында «Татарстанның союз статусы турындагы закон проектын эшләү буенча гражданнар комитеты»н оештыру турында карар кабул ителә. 1990 ның 30 августында ТАССР ЮС «Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация» кабул иткәч, 1990 ның 19 сентябрендә Татарстан суверенлыгын яклау һәм гамәлгә ашыру ком-тының Учредительләр съездын әзерләү өчен составында 52 кеше булган Респ-ка координацион советы оеша. 1990 ның 25 ноябрендә Казанда «С.» Учредительләр съезды уза, анда оешманың уставы һәм программасы кабул ителә, ш.у. составында 27 кеше булган координацион совет сайлана (рәисе — Ә.Г.*Мәхмүдов*). 1991 нең 1 феврале «С.» ТР МК каршында теркәлә.

«С.» ком-ты уставы индивидуаль, коллектив һәм ассоциация әгъзалыгын күздә тота. 1990 еллар башында 1 меңгә якын индивидуаль әгъза исәпләнә. Идея-сәяси доктрина оешма программасына (1990 ның 25 ноябрендә кабул ителә), «Татарстан Республикасы дәүләт суверенлыгын ныгыту юллары һәм хокукый нигезләре» ТР дәүләт суверенлыгын беркетү һ.б. документларга нигезләнә (1993 тә Ә.Г.Мәхмүдов һәм Г.Г.Мортазин тарафыннан эшләнә, 1996 да кабул ителә). «С.» ком-тын оештыруның төп максаты буларак «республика территориясендә яшәүче барлык халыкларның бәхетле киләчәге хакына Татарстанның ныклы дәүләт суверенлыгына ирешү» игълан ителә (респ-ка суверенлыгында татар халкының үзбилгеләнүгә хокукын гамәлгә ашыру күз алдында тотыла). «С.» программасында совет чорында яшәп килгән һәм «үзенең сәләтсезлеген, халыкларның, милләтләрнең һәм аларның дәүләти берләшмәләренең табигый үсешенә каршылыгын күрсәткән» тоталитар режимның адм. команда системасы кискен тәнкыйтьләнә. 1991 нең ахырына кадәр ком-т җитәкчелеге Татарстанга союздаш респ-ка статусын һәм респ-када Союз килешүенә мөстәкыйль кул кую хокукын бирүләрен таләп итә, ул чорда әлеге килешү өстендә эш алып барыла. «С.» әгъзалары эшләгән һәм 1991 нең 21 маенда ТССР ЮС Президиумына тәкъдим ителгән Татарстан Конституциясе проектының бер варианты шул принципларга нигезләнә. СССР таркалгач, ком-т җитәкчелеге респ-ка бәйсезлеге идеясен алга сөрә, шул рәвешле Россия б-н мөнәсәбәтләр халыкара хокук принципларына нигезләнергә тиеш була. Шул җирлектә «С.» ком-ты җитәкчеләре дәүләт хакимиятенең федераль органнарына сайлауларны респ-када уздыруга даими рәвештә каршы чыгалар, ш.у. *«Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында»* Шартнамәнең имзалануына (1994 нең 15 феврале) тискәре карыйлар.

«С.» ком-ты программасында демократия һәм кеше хокукларына, идеяләренә, бигрәк тә халыкларның үзбилгеләнүгә хокуклары бирелгәнлек игълан ителә. Төп игътибар татар халкының милли проблемаларына юнәлтелә; аның бергә тупланып ныгуы, респ-кадагы ике дәүләт теленең берсе буларак, татар теленә «зур уңайлылык режимы» булдыру зарурлыгы ассызыклана (соңрак күп тапкырлар Татарстанда татар теленә бердәнбер дәүләт теле статусы бирү таләбе дә куела). «С.» ком-ты активистлары тарафыннан төрле елларда вакытлы матбугат басмалары — «*Суверенитет*» (1991–95), «Коммерсант Татарстана» (1992–93), «*Независимость*» (1992–93), «Бәйсезлек» (1992), «Бәйсез Илем» (1994) г-талары, «Независимая Отчизна» (1994) ж-лы чыгарыла.

«С.» ком-ты үз эшчәнлегенең башыннан ук Татарстан җитәкчелегенә оппозицион көч буларак чыгыш ясый. Респ-каның тулы бәйсезлегенә омтылуны игълан итеп, ком-т җитәкчеләре 1990 еллар башында татар радикаль сәяси хәрәкәтләре, аеруча «*Иттифак» Татар милли бәйсезлек партиясе* б-н үзара тыгыз элемтәдә тора: уртак митинглар, агитация кампанияләре уздыра. «С.» ком-ты активистлары 1992 дә *Милли Мәҗлес* (Милли җыелыш) һәм Татарстанның Респ-ка партиясен оештыруда һәм аның эшчәнлегендә катнаша. 1991–92 еллар чигендә ком-т утырышларында «Татарстан бәйсезлеге»н яклау максатыннан милли гвардия оештыру кирәклеге турындагы мәсьәлә карала (1991 нең 26 декабрендә «Милли гвардия концепциясе» кабул ителә); еш кына Татарстан халкының Россия армиясе сафларында хезмәт итүен туктату зарурлыгы хакында белдерелә. 1994 тә Ә.Г.Мәхмүдов тырышлыгы б-н Татарстан бәйсезлеге партиясе (ТБП) оеша. Оештыру съезды 1994 нең 18 маенда Казанда уза, рәис итеп Ә.Г.Мәхмүдов сайлана. ТБП барлыкка килү аны оештыручыларның РФ һәм ТР арасындагы килешүнең имзалануын хата буларак бәяләве, Татарстанның тулы бәйсезлеген яклавы б-н бәйле. Әмма ТБП актив эшчәнлек җәелдерә алмый. 1996 ның 27 апрелендә Казанда «С.»ның 2 нче съезды була, анда оешманың да һәм гомумән татар милли хәрәкәтенең дә кризис хәлендә булуы билгеләп үтелә. 1996 дан башлап «С.» тарафдарларының сәяси активлыгы кими башлый. Киң иҗтимагый хуплау җитенкерәмәгәч, ком-т җитәкчелеге татар милли хәрәкәтенең башка оешмалары, бигрәк тә БТИҮ вәкилләре б-н элемтәләр урнаштырырга омтыла. 1990 еллар ахырында «С.» хәрәкәте таркала.

*Әд.:* Терентьева И.В., Беляков Р.Ю., Сафаров М.Ф. Республика Татарстан: Политические партии, движения, лидеры. К., 2001.

*М.Ф.Сәфәров.*

**«СУВЕРЕНИТЕ́Т»**, айлык иҗтимагый-сәяси газета. Күпмилләтле «*Суверенитет*» демократик хәрәкәте органы. 1991 елның июленнән 1995 кә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә. Төрле еллардагы баш мөхәррирләре — А.Х.Мәннанов, Ә.Г.*Мәхмүдов*. Газетаның лозунгы — ТР Конституциясеннән алынган цитата: «Татарстан — мөстәкыйль демократик дәүләт». Актив авторлары арасында — М.Әхмәтҗанов, Р.Галләмов, З.Зәйнуллин, Ә.Кәримуллин, А.Мәннанов, Ә.Мәхмүдов, Г.Мортазин, Р.Мөхәммәтдинов, Р.Шакиров. Газета 1990 еллар башында татар милли-демократик хәрәкәте күтәрелеше чорында чыга. Материалларның күп өлеше Татарстанның дәүләт статусына, аларны хәл итү өчен көчләрне бергә туплап ныгыту буенча татар милли оешмалары хәрәкәте мәсьәләләренә багышлана. Редакция тарафыннан татар халкының үзбилгеләнүгә хокукын гамәлгә ашыру формасы буларак ТРның тулы мөстәкыйльлеген раслау идеясе уздырыла. Респ-каның элеккеге хәле колониаль буларак характерлана, РФ б-н үзара мөнәсәбәтләрне халыкара хокук принципларында урнаштыру мөһимлеге ассызыклана. Милли Мәҗлес эшчәнлеге, Милли Мәҗлес платформасында берләшкән сәяси оешмалар эше яктыртыла, рәсми документлар, Милли Мәҗлес депутатлары исемлеге басыла. Милли хәрәкәт идеологлары тарафыннан эшләнгән «Татар халкы Конституциясе» проекты, Милли Мәҗлес чакыру буенча оештыру ком-тына Бөтендөнья татар корылтаенда (1992) карау өчен тәкъдим ителгән «ТРның дәүләт мөстәкыйльлеге турында»гы, «Милли Мәҗлес турында»гы закон проектлары басыла. «Суверенитет» хәрәкәтенең Бөтентатар иҗтимагый үзәге, «Иттифак» фиркасе, Ш.Мәрҗани исем. җәмгыять «Азатлык» — татар яшьләренең берлеге, Татарстанның респ-ка партиясе б-н берлектә сәяси белдерүләре чыга, 1994 тә «Суверенитет» хәрәкәте Уставы дөнья күрә. Газета үз битләрен «ТРның хәрби доктринасы» («Военная доктрина РТ») мәкаләсенә, «ТР суверен дәүләтенең хокукый нигезе һәм аны ныгыту юллары» («Правовые основы и пути закрепления государственного суверенитета РТ») концепциясенә һ.б.га бирә. Редакция ТР җитәкчелеген респ-каның мөстәкыйльлеген раслау һәм яклауда килешүчән сәясәте өчен тәнкыйтьли. «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» шартнамәсе проектын бастыра. Газета Татарстан территориясендә РФ референдумнарын һәм сайлауларын уздыруга каршы чыга, федераль Үзәк мәнфәгатьләрен чагылдырган сәяси хәрәкәтләрне тәнкыйтьли, «Вечерняя Казань», «Известия Татарстана», «Казанские ведомости» г-талары б-н фикер алыша. Россия һәм Татарстандагы сәяси вакыйгалар һәм аларга бәяләмәләр аерым биттә «Вакыйга — Фактлар — Фикер алышу» («События — Факты — Отклики») сәхифәсендә яктыртыла. Материалларда татар теле һәм мәдәнияте язмышы, татар диаспорасы, ш.и. Башкортстан татарларының хәле темалары даими күтәрелә. Респ-кадагы икътисади хәлләр, аның икътисади мөстәкыйльлеге формалашу, хуҗалык итүнең яңа формалары үсешенә багышланган материаллар аерым биттә «Татарстанда коммерция яңалыклары» («Коммерческие новости Татарстана»), «Татарстан коммерсанты» («Коммерсант Татарстана») дигән исемнәр б-н басыла. Әдәби сәхифәләрдә Ә.Мәхмүдов, Р.Камәртдинов, В.Кузнецов, Р.Батрашёв һ.б. шигырьләре бирелә. Күп кенә саннарның тарихи-мәдәни мирас бүлегендә Р.Г.Фәхретдиновның «Алтын Урда һәм татарлар» китабыннан өзекләр басыла. Газета финанс авырлыгы һәм милли хәрәкәтнең сүлпәнәюе сәбәпле чыгудан туктый.

*Р.А.Айнетдинов.*

**СУВО́РОВ** Фёдор Матвеевич (14.9.1845, Пермь губ., Верхотурье өязе Кувшинский Гороблагодатский завод — 19.6.1911, Казан), математик, геометр, саф математика д-ры (1885), атказ. проф. (1896). 1867 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: практик механика кабинеты каршындагы музей хезмәткәре (1869–71), саф матем. каф. профессоры (1885 тән), физика-математика ф-ты деканы (1899–1905); бер үк вакытта Казан югары хатын-кызлар курсларында математика фәннәрен укыта (1870–80). Хезмәтләре күп үлчәнешле дифференциаль геометриягә карый. С.ның өч үлчәнешле системаларның характеристикалары турындагы диссертациясе («О характеристиках систем трёх измерений»,1871) геометриядә уйланма элементлар теориясе буенча (Н.И.Лобачевский, немец математиклары К.Гаусс һәм Г.Риман идеяләре үстерелә, өч үлчәнешле риман фәзаларының дифференциаль инвариантлары өйрәнелә) Россиядә беренче хезмәт була. Интеграль исәпләүләр, сызма һәм аналитик геом. буенча дәреслекләр авторы. Табигыятьчеләр җәмгыятенең матем. секциясен оештыручыларның берсе. Н.И.Лобачевский хезмәтләре җыентыгының 1 нче томын басмага әзерләүдә катнаша; «Учёные записки Императорского Казанского университета» ж-лы мөхәррире (1892 дән).

Х е з м.: Интегральное исчисление. К., 1884; Определённые интегралы. К., 1887; Вариационное исчисление. К., 1889.

*Әд.:* Ефимов М.Ф. Воспоминания о профессоре Ф.М.Суворове. К., 1912; Олоничев П.М. Казанский геометр Фёдор Матвеевич Суворов // Ист.-мат. исслед. 1956. Вып. 9.


**СУВО́РОВКА** посёлогы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 31 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 2,5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 3 кеше (руслар) яши. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новопоселённые Ключищи, Ключищи исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 108 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 31 ир-ат; 1859 да — 190, 1897 дә — 198, 1908 дә — 206, 1920 дә — 229, 1926 да — 223, 1938 дә — 252, 1949 да — 52, 1958 дә — 93, 1970 тә — 68, 1979 да — 42, 1989 да — 25, 2002 дә — 16 кеше.

**«СУВО́РОВЧА КЫСРЫКЛА́У»**, фронт газетасы. Байкал арьягы-Амур хәрби округы сәяси идарәсе органы. 1945 елның 28 июненнән 1947 нең августы ахырына кадәр татар телендә нәшер ителә. Башта Чита шәһәрендә, Япония б-н сугыш башлангач — Кытай терр-ясендә, сугыш тәмамлангач — Хабаровск шәһәрендә басыла. Мөхәррире — М.Минһаҗев. Газетада К.Әхмәров, А.Әхмәт, Ф.Басыйров, А.Шамов эшли. «С.к.»да Байкал арьягы фронты частьларының Квантун армиясенә каршы хәрби хәрәкәтләре яктыртыла.

*Әд.:* Шамова А. Печать, рождённая в огне // Казань. 2007. № 7.

**«СУВО́РОВЧЫ»**, фронт газетасы. 2 нче Балтыйк буе фронтының сәяси идарәсе органы. 1944 елның февраленнән 1945 кә кадәр татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире — М.Шәймәрданов. Хәрби хәбәрчеләре — Р.Баһау һәм И.Гурьев.

**СУГА́Н** (Allium), суганчалар семьялыгыннан ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы; яшелчә культурасы. ТРда 10 төре бар. Башлы С. иң киң таралган. Икееллык үсемлек. Беренче елда суганын формалаштыра, икенче елда чәчәк ата һәм орлыклар барлыкка килә. Чәчәк төркеме — чәчәк төбендә ялган чатыр. Чәчәкләре вак, ике җенесле, ак, шәмәхә, алсу, сары, яшькелт төстә, читтән серкәләнүче (бал кортлары, чебеннәр ярдәмендә). Җимеше — тартмачык; орлыклары кара, каты тышчалы. Яфраклары көпшәсыман, куыш. Тамыр системасы көчсез. Тамырларының төп массасы 5–20 *см* тирәнлектә була. Суганнары яссы, озынча һәм түгәрәк; сортына карап, 2,4–14% шикәр, 2–23,9 *мг* % C витамины, эфир майлары була; яфракларында 25–47,7 *мг* % C витамины, 1,3–5,9 *мг* % A провитамины бар.



Башлы суган.

Башлы С. дым ярата. Уңдырышлы, әче булмаган, чүпсез туфракны өстен күрә. Иң яхшы элгәрләре — кәбестә, томат, кыяр, көзгә бөртеклеләр, бәрәңге. Тәме буенча башлы С.ны ачы, ярымачы, төчегә бүләләр. Респ-када якынча 2500 *га* мәйданда үстерелә, орлыклык вак суган уңышы — 1 *га* дан 70–120 *ц*, су-

ганы — 100–400 *ц*, орлыгы 5–10 *ц* чыга. Чәчүгә рөхсәт ителгән сортлары: «Мячковский 300» (1985), «Штутгартен Ризен» (1988), «Бессоновский местный», «Арзамасский местный», «Стригуновский местный», «Татарский».

ТР халкы күпьеллык С. үстерә: батун — «Русский зимний» сорты (чәчүгә 2001 дә рөхсәт ителә), суган формалаштырмый, бер урында 4 елга кадәр үсә, уңышы 1 *га* дан 300 *ц* га кадәр; шнитт — «Медонос» сорты (1990); ялпак суган — озын тасма кыяклы суган, аз үстереләә, уңышы 1 *га* дан 250 *ц* га кадәр.

Төп корткычлары: суган чебене, кәбестә ябалакчыгы, гади чикерткә, дүртаяклы сарымсак талпаны, тамыр талпаны, сабак нематоды, табак трипсы. Авырулары: муен черege, ялган ончыл чык һ.б.

*Әд.:* В о р о б ь ё в а А.А. Лук. М., 1980; Ваш огород: Маленькая энцикл. М., 1995.

**«СУГЫ́Ш САФЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. Төньяк фронтның Мөселман солдатлары ком-ты органы. 1917 елның 5 ноябреннән 1918 нең 18 февраленә кадәр Псков шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире — М.Н.*Килдебәков*.

**«СУГЫ́Ш ХӘБӘРЛӘРЕ́»**, хәрби газета. *Керәшен* татарлар өчен чыгарылган беренче вакытлы басма. 1915 елның февраленнән 1917 нең декабренә кадәр Вятка шәһәрендә татар телендә кириллицада нәшер ителә, якынча 40 саны чыга. Вятка губернасының губернаторы А.Г.Чернявский күрсәтмәсе б-н керәшен татарларны Беренче бөтендөнья сугышы фронтларындагы хәрби хәрәкәтләр барышы б-н таныштыру максатыннан оештырыла. Удмурт («Войнаысь ивор») һәм мари («Война увер») телләрендә дә басыла. Оештыручысы һәм мөхәррире — Вятка әҗнәби миссионер курслары җитәкчесе, Казан руханилар академиясен тәмамлаган П.П.Глезденёв. 1915 нең ахырында губерна земствосы газетаны финанслауны туктата һәм Глезденёв аны үз акчасына чыгара башлый. 1917 дә земство газетага акча бирүне яңарта. «С.х.» б-н Д.Григорьев, Р.Давлей, Н.Егоров, Р.Лопухин, Г.Романов, В.Соловьёв хезмәттәшлек итә. Газета керәшен «*Дус*» г-тасы редакциясе б-н тыгыз аралашып эшли. Төп игътибар фронтлардагы Россия һәм союздаш гаскәрләрнең уңышларына бирелә, «Җиңгәнчегә кадәр сугыш» лозунгына таяна. Рус армиясенең уңышсызлыклары, массакүләм дезертирлык, солдатларның приказларга буйсынмавы һәм дошман б-н дуслашу, нигездә, большевикларның җимерү эшчәнлеге б-н аңлатыла. Глезденёв газетаны миссионерлык идеяләрен, «Дин, патша һәм Ватан өчен!» лозунгын пропагандалау өчен файдалана. 1916 дан «С.х.» битләрендә җирле әҗнәби халыклар тормышы, кооперация турындагы материаллар, санитария һәм а.х.н алып бару буенча киңәшләр бастырыла. Газета Февр. рев-циясен хуплый, Россиянең конституцион-респ-ка юлы б-н үсешенә юнәлтелгән демократик үзгәрешләрне яклый, Вакытлы хөкүмәт, Эшче һәм солдат депутатлары советы эшчәнлеген даими яктыртып бара. Сайлау системасын демократияләштерү һәм җирле үзидарә органнарының, беренче чиратта өяз земстволарының, вәкаләтләрен киңәйтү тәфсилләп анализлана. Газета Учредительләр җыены сайлау алды компаниясендә актив катнаша, Вятка губернасының сәяси оешмалары кандидатлары б-н таныштыра. Аның битләрендә Идел буеның аз санлы халыклары вәкилләренең съездлары эше киң яктыртыла (Казан, 1917 ел, май, август).

1917 нең 1 сентябрендәге санында Россияне федератив демократик респ-ка итеп үзгәртергә тәкъдим иткән август съездының 4 эшче комиссиясе карарлары басыла. Редакция тарафыннан керәшен һәм татар-мөселманнарның этник тарихындагы аермалар турындагы фикер хуплана. Вятка губерна Советларының өлкәдә совет хөкүмәте рәсми төстә игълан ителгән 1 съездыннан соң (1918 нең 5–8 гыйнвары) газетаның исеме «Хәбәр йөртүче» дип үзгәртелә. Ул консерватив-монархик юнәлештән самодержавиене бәреп төшерүне хуплауга кадәр, совет хакимиятенә лояльлек б-н тәмамланган эволюция ясый.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Г р и г о р ь е в А.Н. Кряшенский вопрос в Татарии и его разрешение Советской властью: Дис. ... М., 1945; Н а с ы р о в Т.М. Репрессии против небольшевистской татарской прессы в 1917–1919 годах // Отеч. история. 2000. № 4.

*Т.М.Насыйров.*

**СУГЫШЛЫ́** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 21 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 114 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1927 дә нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Бөгелмә волостенда. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1938 дә — 228, 1949 да — 225, 1958 дә — 154, 1970 тә — 152, 1979 да — 146, 1989 да — 118, 2002 дә — 103 кеше.

**СУГЫШЛЫ́** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 20 *км* көньяк-көнбатыштарак, Урман Чишмәсе елгасы буенда. 2010 елда 514 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1730 елларда нигез салына. 1920 елларга кадәр — Шугышлы, рев-циягә кадәрге чыганакларда Надырова буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, Бөгелмә өязе авылларында өй салу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 3 мәчет, 3 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3410 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Спиридоновка волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1746 да — 30, 1785 тә — 91 ир-ат; 1795 тә — 306, 1859 да — 391, 1889 да — 1252, 1897 дә — 1653, 1910 да — 2268, 1920 дә — 2268, 1926 да — 1452, 1938 дә — 1341, 1949 да — 1241, 1958 дә — 1176, 1970 тә — 1057, 1979 да — 832, 1989 да — 577, 2002 дә — 577 кеше. С.да Сов. Союзы Геройлары Г.Г.*Гафиятуллин*, М.Х.*Хәлиуллин*; Соц. Хезмәт Геройлары Ш.Г.*Галиев*, Җ.С.*Зәйнагов* туган.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**«СУГЫШЧА́Н АЛЛАСЫ́З»**, айлык фәнни журнал. Сугышчан алласызлар берлегенең Үзәк советы органы. 1925 елның августыннан 1937 нең ноябренә кадәр Мәскәүдә татар телендә нәшер ителә, барысы 172 саны чыга. 1925–32 дә (5 нче санга кадәр) «Фән һәм дин» исеме б-н дөнья күрә. Төрле еллардагы мөхәррирләре — Г.*Гафуров-Чыгътай*, Г.Алтай, И.Наильский, Б.*Мансуров*, И.Агишев. Журнал б-н Х.Арский, С.Атнагулов, Г.Әхтәмов, Г.Басыйри, М.Басыйров, Ф.Галәви, М.Давыдов, Г.Ибраһимов, Ф.Кәрими, Г.Касыймов, М.Килдебәков, М.Максуд, Г.Мансуров, Ш.Мостай, В.Садри, С.Сәетгалиев, С.Тарханов, Ш.Шәйхи, Г.Шәрәф, В.Шәфигуллин, М.Яушев һ.б. хезмәттәшлек итә. Басманың максаты — атеизмны пропагандалау һәм дин б-н көрәш. «Дингә каршы көрәш — социализм өчен көрәш» девизы б-н чыга. Исеме үзгәргәнче, журналда астрономия, метеорология, биол., мед., физиол. һ.б. табигыять фәннәре буенча күп санда мәкаләләр басыла. Журналда ислам, христианлык, буддачылык, иудаизмның барлыкка килү тарихы һәм, асылда, ш.у. атеизм туу һәм аның үсешенә багышланган язмалар урын ала. Материалларның күп өлеше (ил тарихы, авылны үзгәртеп кору, мәдәни рев-ция, индустрияләштерү турында) тормышның соц. күренешен пропагандалауга һәм татар халкының киң катлавын соц. төзелешкә җәлеп итүгә юнәлдерелә. «Тәнкыйть һәм библиография» сәхифәсендә табигыять фәннәре һәм дини тематика буенча әдәбият турында мәгълүмат урнаштырыла. Редакция мөселманнар арасында алласызлар хәрәкәте оештырырга омтыла. 1927 дә журнал «Һәр волостька — атеистлар оешмасы» лозунгы б-н чыга. Исеме үзгәртелгәннән соң, редакция басманың дингә каршы юнәлешен көчәйтә, игътибарын СССРда дини оешмаларның соц. төзелешкә каршы хәрәкәтенә туплый. Шунда ук табигыять фәннәре мәгълүматлары, марксистик-ленинчыл фәлсәфә тезислары, матур әдәбияттан мисаллар китерелә. Журналда татар матбугатының, ш.и. «Игенчелек», «Колхозчы», «Кызыл Татарстан», «Эшче» г-таларының дингә каршы мәкаләләре анализлана. Редакция көрәшне 2 фронтта алып барырга кирәк дигән фикердә тора: «сул тайпылышка» каршы, ягъни дини оешмаларны тыю һәм дин б-н килешүчәнлеккә каршы. СССРдагы дингә каршы оешмаларның эшчәнлеге һәм эш ысуллары, халыкара дингә каршы хәрәкәт проблемалары, чит илләрдәге дини оешмаларның «контрреволюцион» эшчәнлеге системалы рәвештә яктыртып барыла, методик ярдәмлекләр басыла. Урыннардагы дингә каршы эш иллюстрациясе сыйфатында авыл хәбәрчеләренең мөселман дин эшлекләләрен кысрыклау, манараларны кисү, мәчетләрне клублар, уку йортлары, кино заллары итеп үзгәртеп кору фактлары турындагы кыска язмала-

ры басыла. Журнал эшчәнлегенең соңгы елларында аның битләрендә татар иҗади интеллигенциясен һәм әдәбият-сәнгать классикларын тәнкыйтьләү көчәя (1936 ның 5 нче санында «Тукай иҗатында милләтчелек һәм дин» дигән мәкалә басыла). Журнал милли телләрдәге матбугатны үзәктән алуга бәйле рәвештә ябыла.

**«СУГЫШЧА́Н АЛЛАСЫ́З»**, атналык газета. ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты һәм Сугышчан алласызлар берлегенең Татарстан өлкә советы органы. Наширләре — «*Красная Татария*» һәм «*Колхозник Татарии*» г-талары. 1929–33 елларда Казанда татар телендә нәшер ителә (1932 нең 1 июненә кадәр «Динсезләр» исеме б-н чыга). Төрле елларда-гы мөхәррирләре — М.*Хөсәенов*, В.Әхмәров, Ж.Жәрмәкиев, Ж.Хуҗиев, Яушев һ.б. Газета б-н Г.Газизов, А.Нурмөхәммәтов, Д.Фатихи, Х.Шәфигуллин, Г.Шияси һ.б. хезмәттәшлек итә. «С.а.» «Дингә каршы көрәш — социализм өчен көрәш» лозунгы б-н чыга. Фәнни атеизмның төп кагыйдәләрен пропагандалый. СССРда һәм аннан читтә дингә каршы пропагандганы оештыру, фән һәм техника яңалыклары б-н таныштыра.

**«СУГЫШЧА́Н АЛЛАСЫЗЛА́Р»**, фәнни журнал. ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты һәм Сугышчан алласызлар берлегенең Татарстан өлкә советы органы. 1929–33 елларда Казанда татар телендә нәшер ителә.

**СУДА́ ТУПЛЫ́ УЕ́Н** (ватерпол), суда туп б-н командалы спорт уены. 7 шәр кешелек ике команда арасында 20х30 *м* үлчәмле (2 *м* тирәнлектә) турыпочмаклы мәйданда алып барыла, алгы як уртасында киңлеге 3 *м* һәм биеклеге су өстеннән 0,9 *м* булган капкалар куела. Казанда С.т.у. 1940 елларның 2 нче яртысыннан үсеш ала; аны нигезләүчеләр — А.Х.Панайопти, Ф.Ботбеков, О.А.Новак. 1948 дә ТАССР җыелма командасы беренче тапкыр Куйбышев шәһәрендә халыкара матчта катнаша. 1950 елларда С.т.у. «Спартак», «Динамо» ирекле спорт җәмгыятьләрендә һәм ДОСААФта үсеш ала. Шәһәр ярышлары 1961 дән алып барыла. 1974 тә Казанда С.т.у. буенча 8 нче Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе ачыла (1974 тән директоры В.А.Панайота, 2001 дән В.С.Денисов), тәрбияләнүчеләре арасында Бөтенроссия Яшьләр уеннары чемпионнары (1977, 1981, 1985), СССР (1986), (1983, бронза), Россия (2011, 2013 ТР җыелма командасы составында) (2006, көмеш) яшүсмерләр беренчелекләрендә, Россия укучылар спартакиадаларында (2011, көмеш), спорт мәктәпләренең 1 нче җәйге Бөтенроссия спартакиадаларында (2012) җиңүчеләр бар. 2009 дан Казанда С.т.у. буенча Е.Н.Мишин истәлегенә бөтенроссия турнирлары уздырыла. С.т.у. Казанда олимпия резервындагы Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (Идел буе район хакимияте бассейны), С.т.у. буенча 8 нче Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә, олимпия резервындагы уч-щедә, «Ак бүре», «Олимп», «Буревестник», «Бустан» спорт комплексларындагы секцияләрдә җәелдерелә. СССР, Европа, дөнья чемпионнары һәм Олимпия уеннарында катнашучылар һәм медаль алучылар (СССР һәм Россия җыелма командалары составында) арасында Казан спортчылары бар: Россиянең атказ. спорт остасы М.С.Закиров, И.Х.Зиннуров; халыкара класслы спорт остасы А.Бойко, О.Владимиров, И.Н.Горбач, Н.И.Шәрәфиев; Россиянең спорт осталары А.Зиннәтуллин һәм А.Одинцов — Казанда Бөтендөнья җәйге Универсиадада (РФ җыелма командасы составында) көмеш медаль алучылар. Иң яхшы тренерлар: РСФСРның атказ. тренеры В.А.*Лелюх*, В.Б.Сахаров; РФнең атказ. тренеры В.А.Горюнов; халыкара категорияле судьялар А.А.*Афанасьев*, И.Х.Зиннуров. 1993 тән ТРның «Органик синтез» АҖ каршындагы «Синтез» командасы С.т.у. буенча Россия чемпионатының югары лигасында чыгыш ясый, 2014 тән С.т.у. буенча «Синтез–Академия–Казан» студентлар командасы («Синтез» клубы һәм Идел буе физкультура, спорт һәм туризм академиясе уенчылары) Россия чемпионатында катнашуга билгеләнә (икесендә дә баш тренер — И.Х.Зиннуров).

**СУДАКЛА́Р**, сылалар (Stizostedion), алабугалар семьялыгыннан. 5 төре билгеле, Евразиядә, Төньяк Америкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади С. (S. lucioperca) барлык сусаклагычларда һәм Идел б-н Каманың барлык зур кушылдыкларында яши. Озынлыгы 60–70 *см*, авырлыгы 2–4 *кг*. Гәүдәсе озынча, ян-яктан кысылган, вак тәңкә б-н капланган. С. — өске һәм аскы казналыкларында нык аерылып торучы казык тешле һәм шома өлештән торучы саңак капкачлы ерткыч. Сырты яшькелт, корсагы көмешсыман-ак төстә. Гәүдәсенә аркылы коңгырт сызыклар төшкән. Беренче сырт йөзгеченең нурлары чәнечкеле. Уылдыгын апрель–майда яр буе участокларына, ш.у. тирән сулыкларга берьюлы чәчә. Уылдык бөртекләре, ябышып, челтәр рәвешен ала. Җенси җитлегү чоры — ата балыкларда 5–6, аналарда 6–7 яшьтә. Башлыча, кәсәбәчелек әһәмияте булмаган вак балыклар (кыртыш, җилембалыклар, алабуга, вак балык) б-н туклана. Кәсәбәчелек объекты.

**СУДА́Н ҮЛӘНЕ́** (Sorghum sudanense), суданика, судан соргосы, кыяклылар семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Кыргый төре Африкада Нил үзәнендә очрый. Терлек азыгы буларак Көнбатыш Европада, Төньяк һәм Көнчыгыш Африкада, Һиндстан, Америка, Австралия, Россиядә үстерелә. С.ү.нең куагы күп санлы (яхшы шартларда 120 гә кадәр) 0,5–3 *м* биеклектәге яфраклы сабаклардан барлыкка килә. Яфраклары ланцетсыман, шома, аксыл-яшел. Чәчәк оешмасы — озынлыгы якынча 40 *см* лы җәенке себеркәч. Җимеше — бөртекчә, башак кабыгы б-н тыгыз капланган. 1000 бөртекчәнең авырлыгы 10–15 *г* һәм күбрәк була. Чабып алганнан соң да яхшы үсә. Яшел азык һәм үлән өчен башак җибәрү вакытында әзерлиләр. 1 *га* дан 700 *ц* яшел азык, 60–100 *ц* печән чыга. 100 *кг* печәндә 57 азык берәмлеге һәм 7,4 *кг* үзләштерелә торган протеин бар. Үзе генә дә, ш.у. катнаш чәчүлекләрдә (чина, соя, вика, люпин, көнбагыш һ.б.) үстерелә. 3–4 тапкыр чабып алырга мөмкин. Орлыкның чәчү нормасы 1 *га* га 14–22 *кг*, орлыкны күмдерү тирәнлеге — 3–8 *см*. Татарстанда зур булмаган мәйданчыкларда яшел конвейр системасында печән, үлән оны әзерләү өчен үстерелә. «Кинельская 100» (1983), «Тиганская» (2002), «Аида» (2003) сортлары районлаштырылган.

*Әд.:* Однолетние кормовые культуры. М., 1967.

*Р.Ә.Әсретдинова.*



М.В.Суднишников.

**СУДНИ́ШНИКОВ** Михаил Владимирович (21.11.1919, Казан губ., Алабуга өязе Бондюг Заводы пос. — 2.12.1985, Мәскәү), Сов. Союзы Герое (31.5.1945), полковник. Ленинград хәрби уч-щесен (1941), «Выстрел» курсларын (Мәскәү өлкәсенең Солнечногорск ш., 1946), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (Мәскәү, 1950) тәмамлый. 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 694 нче укчы полкның (33 нче армиянең 383 нче укчы дивизиясе) батальон командиры. Көнбатыш, 1 нче Белоруссия һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Мәскәү сугышында (1941–42), Ржев-Вязьма операциясендә (1942), Смоленск (1943), Белоруссия (1944) һәм Берлин (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Берлинда дошманнар төркемен юк итү операциясендә батырлык күрсәтә: 1945 нең 27–28 апрелендә С. җитәкчелегендәге батальон, дошманның тере көчләре һәм техникасына зур зыян китереп, бернечә торак пунктны яулап ала. Сугыштан соң армиядә хезмәтен дәвам итә. 1951–58 дә М.В.Фрунзе исем. Хәрби академиядә укыта. 1959 дан запаста, СССР ФАнең Элементорганик кушылмалар ин-тында (Мәскәү) эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**СУДНОЛА́Р ТӨЗҮ́**, авыр машиналар төзү тармагының суднолар төзү һәм судноларны ремонтлау з-дларын, фәнни-конструкторлык оешмаларын һәм приборлар төзү пр-тиеләрен берләштергән юнәлеше. Татарстан терр-ясендә агач С.т. 10 йөздән мәгълүм. Аның барлыкка килүе *елга транспортының* актив үсеше, С.т. өчен яраклы агачка (имән, мачта нараты) бай урманнар булуы б-н бәйле. 15 йөздә балта осталарының Казан янындагы Бишбалта торулыгында эре С.т. үзәге формалаша. Төбәк Рус дәүләтенә кушылганнан соң (16 йөз), җирле С.т. воеводалар күзәтчелегендәге «патша эше» дип игълан ителә. 17 йөздә елга корабльләре б-н бергә анда хәрби диң-

гез корабльләре төзи башлыйлар. Суднолар «балта белән эшләнгән», ягъни тупас ярылган такталардан, тимер детальләр юк дәрәҗәдә: аз кулланылып төзелә һәм, кагыйдә буларак, бер навигация чорында гына файдаланыла. Төзүдә традицион ысуллар кулланыла, судноларның конструкциясе әллә ни камилләшми. Пётр I идарә иткәндә, техник һәм оештыру ягыннан тармак эшчәнлеге күпкә яхшыра: су көченә нигезләнгән «яру тегермәннәре», эшчеләр арасында билгеле бер дәрәҗәдә белгечлекләр барлыкка килә, мәҗбүри рәвештә С.т.нең алдынгы ысуллары, чит илләрдә һәм Россиядә кабул ителгән яхшыртылган типтагы конструкцияләр гамәлгә кертелә, төзелгән суднолар саны күпкә арта (18 йөз башында Казанда һәм Ослан авылында ел саен 60–70 судно төзелә). Корабльләр төзүгә яраклы урманнарны саклау өчен, төбәктә хосусый С.т. тыела (1697); имән, мачта нараты, карама, корычагач саклаулы агач төрләре дип игълан ителә (1717). 1718 елда *Казан адмиралтействосы* ачылганнан соң, агач С.т. тагын да киңрәк колач ала. Верфьләрдә зур фрегатлар, галеотлар, кече суднолар төзелә. 1756–68 дә Россиядә беренчеләрдән булып ат көче б-н хәрәкәткә китерелүче двигательләр куелган үзйөрешле «коноводка»лар суга төшерелә. Бу чорда С.т. б-н төбәк халкының төрле шөгыльләре — пәҗе-канат (корабль арканнары, сүс), чыпта (җилкән киндере) сугу, урман (төзелеш материалы), сумала кайнату (корабль корпусларына һәм арканнарына сеңдерү өчен дегет), тимерчелек (якорьлар, кадаклар, атламалар, болтлар) кәсепләре тыгыз бәйләнештә була. Халыкның күпчелек өлеше агач әзерләү йөкләмәләрен үтәүгә җәлеп ителә (к. *Лашманнар*). 19 йөзнең 1 нче яртысында Казан Идел буендагы төп С.т. үзәге булудан туктый, бу урынны Түбән Новгород һәм Әстерхан били.


19 йөз уртасында пароходлар киң файдаланыла башлау б-н судно ремонтлау остаханәләрен оештыруга керешәләр. Алар судноларның кышлау һәм озак вакытка туктап тору урыннары булып хезмәт иткән затоннарда: «*Кавказ вә Меркурий*» җәмгыятенеке — Спас (1856), «Дружина» җәмгыятенеке — Звенигово (1860), Казан юллар округының казна остаханәләре — Паратск (1898), хосусый пароход хуҗаларыныкы Аракчино, Чаллы, Дербёшка һәм Чистай затоннарында (19 йөз ахыры) ачыла. Флот үсә барган саен, аңа хезмәт күрсәтү күләме дә арта һәм Спас, Звенигово остаханәләре, зураеп, вакытлар узгач станоклар, пар двигательләре һәм пар чүкечләре б-н җиһазландырылган эре заводларга әвереләләр. Ул заводларда баштарак пароходларны чит илләрдән кайтартылган компонентлардан җыя, соңрак өлешчә һәм тулысынча төзи башлыйлар. Мәс., 1869–70 тә Спас затонында Иделдә беренче ике палубалы «Александр II» пароходы җыела, 1882 дә суда утыру тирәнлеге кечкенә, әмма зур йөккүтәрешлелеге б-н аерылып торган, илдә беренче электрлаштырылган «Фельдмаршал Суворов» йөк-пасс. пароходы һәм башка суднолар төзелә. Звенигово затонында илдә беренчеләрдән арт тәгәрмәчле йөк пароходлары (1887–89), ш.у. ихтыяҗ зур булган, сай суларда йөзүче һәм ягулыкка экономияле пароходлар, кечерәк буксирлар төзү үзләштерелә. Күп кенә җирле механика һәм металл эшкәртү пр-тиеләре — Казандагы Свешников һәм Сапожников, Чистайдагы Провоторов, Чаллыдагы Котлов з-длары — төрле судно җиһазлары (казаннар, валлар, якорьлар һ.б.) ремонтлыйлар һәм эшләп чыгаралар. 1917 дә Петроград губернасыннан Паратскига Балтыйк һәм Ижор суднолар төзү з-длары эвакуацияләнә. Окт. рев-циясеннән соң тармак пр-тиеләре национализацияләнә, 1920 елларда алар, башлыча, судноларны вак-төяк ремонтлау б-н шөгыльләнәләр, а.х. инвентаре эшләп чыгаралар. Индустрияләштерү чорында (1929–41) Яшел Үзәндәге (элеккеге Паратск), Чистайдагы, Куйбышев (элеккеге Спас) затоннарындагы пр-тиеләр модернизацияләнә, зурайтыла һәм Татарстан С.т. сәнәгатенең үзәген тәшкил итә. 20 йөзнең 2 нче яртысында С.т. югары технологияле тармакка әверелә. Пр-тиеләрдә яңа корпуслар, яр буенда доклар төзелә, слиплар файдаланыла, судноларны өзлексез һәм эре блоклап җыю, судно механизмнарын эшләү технологияләре үзләштерелә, проектлау-конструкторлык бюролары, приборлар төзүче пр-тиеләр оештырыла, инженер-техник һәм эшче кадрлар әзерләү базасы формалаша. Пр-тиеләр аерым юнәлешләр буенча специальләшә: Чистай з-дына — пасс. һәм буксир судноларын, Куйбышев з-дына танкерларны ремонтлау һәм файдалануга техник хезмәт күрсәтү йөкләнә. Чистайда ш.у. су сыйдырышлылыгы 2 мең *т* га кадәр булган елга суднолары һәм паромнар, Яшел Үзәндә 7 мең *т* га кадәр су сыешлы диңгез һәм елга суднолары төзү үзләштерелә. 1959 да кече зурлыктагы С.т. үсеш ала. Казан авиация ҖБдә тиз арада ил халкында популярлык казанган «Казанка» серияле алюминий көймәләр күпләп җитештерелә башлый. 1990 елларда Казанда һәм Чаллы шәһәрендә катерлар, яхталар һәм понтоннар эшләп чыгаручы кечерәк фирмалар барлыкка килә.

ТР С.т. комплексына *Яшел Үзән суднолар төзү заводы, Чистай суднолар төзү һәм ремонтлау заводы*, В.В.Куйбышев исем. Флот ремонт базасы (Кама Тамагы р-нының шәһәр тибындагы Куйбышев затоны посёлогы), *Яшел Үзән проектлау-конструкторлык бюросы*, Казан электр техникасы з-ды (к. «*Свияга*»), Яшел Үзән «ЭРА» пр-тиесе (судноларга электр-радио аппаратларын эшләп чыгара һәм ремонтлый) һ.б. керә. С.т. кадрларын Казан техник ун-тының Яшел Үзән ф-лы, *Яшел Үзән суднолар төзү техникумы*, Чистайдагы башлангыч һөнәри белем бирү учреждениесе әзерли.

*Әд.:* Шубин И.А. Волга и волжское судоходство. М., 1927; Фурер Л.Н. Влияние судоходства на развитие капитализма в Поволжье (середина XIX в.). К., 1959; Речное судоходство в России. М., 1985; История Отечественного судостроения. В 5 томах. СПБ, 1994–1996.

*С.Г.Белов, Ю.В.Мансурова.*

**СУЕРЛА́Р** (Tetrao), тавыксыманнар отрядындагы көртлек кошлар семьялыгыннан кошлар ыругы. 2 төре билгеле, Европа һәм Азия урманнарында таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — гади С. (T. urogallus) Красный Бор, Бөрсет, Чирмешән, Матюшино, Раифа һ.б. урман массивларында яши. Гәүдәсенең озынлыгы 40–60 *см*, авырлыгы 1,5–4,5 *кг*. Башы зур, яссы, зур сары томшыгының очы ыргаксыман бөгелгән, койрыгы киң руль каурыйлы. Ата кошның аркасы һәм канатлары кара көрән, түше металлсыман ялтыравыклы кара яшел, озынча кара каурыйлы «сакалы», күз өстендә шома кызыл табы бар. Ана затлар коңгырт, ак һәм кара чуар. Утрак кош. Җәен — җиләкләр, коры




Суерлар. 1. Ата зат; 2. Ана зат.

җир моллюсклары һәм лайлачлар, көзен — орлыклар, кышын ылыс, агач бөреләре б-н туклана. Язын ата кошлар үзләренең даими гөрелдәү урыннарына йөри башлый. Гөрелдәүнең иң көчле вакыты май башында, йомырка салу чорына туры килә. Ата кош, туй җырын башкарганда, берничә секундка саңгыраулана. Җирдә оялыйлар. Коңгырт тимгелле 8 саргылт-ак йомырка сала. 28–30 көн утыра. Спорт сунарчылыгы объекты.

**СУ́ЗДАЛЬ ЯНЫНДАГЫ́ СУГЫ́Ш** (1445, 7 июль), Василий II Тёмный б-н Олугъ Мөхәммәд гаскәрләре арасындагы сугышларның берсе. Бу сугыш Олугъ Мөхәммәднең, Сарайда тәхетен югалтканнан соң, Урта Идел буенда үз хакимиятен урнаштыру өчен көрәше вакытында була. Василий II, Олугъ Мөхәммәдне Түбән Новгородтан кысрыклап чыгару өчен, гаскәре б-н шәһәргә юнәлә. Аңа каршы хан улы — Мәхмүд бәк җитәкчелегендәге гаскәр җибәрелә (3500 гә якын кеше). Бәрелеш Суздальга якын җирдә, Нерль елгасы буенда, Спас-Евфимий монастыре янында була. Бөек кенәз гаскәре тар-мар ителә, Василий II күп кенә рус кенәзләре һәм боярлары б-н әсирлеккә төшә, аларны Түбән Новгородка Олугъ Мөхәммәд янына китерәләр. Үзен азат итүләре өчен Василий II алтын, көмеш, атлар, хәрби киемнәр һәм кораллар б-н йолым түләргә килешә, 1392 дә Туктамыш Василий I гә саткан «Мещера җирләре»н (ул җирдә *Касыйм ханлыгы* оеша) ханга бирергә вәгъдә итә. 1445 нең октябрендә Василий II әсирлектән азат ителә,

Олугъ Мөхәммәднең уллары — Касыйм һәм Якуп ханга буйсынган аксөякләр (барысы 500 гә якын кеше) озатуында Мәскәүгә килә. Олугъ Мөхәммәд б-н килешенгәнчә, Василий II аларга төрле адм. вазифалар, ш.у. «туендыру өчен» волостьлар һәм шәһәрләр бирә.

*Әд.:* Х у д я к о в М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; З и м и н А.А. Витязь на распутье: Феодальная война в России XV в. М., 1991; П о х л ё б к и н В.В. Татары и Русь. 360 лет отношений Руси с татарскими государствами в XIII–XVI вв., 1238–1598 гг.: Справ. М., 2000.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**СУЗЫ́К АВАЗЛА́Р**, к. *Вокализм.*

**СУК** Вячеслав Иванович (4.11.1861, Австро-Венгрия, хәзер Чехиянең Кладно ш. — 12.1.1933, Мәскәү), дирижёр, ТАССРның халык артисты (1925). 1879 елда Прага консерваториясенең скрипка классын тәмамлый. 1880–82 дә — Киевта И.Сетовныӊ хосусый операсының, 1882–85 тә Зур театр (Мәскәү) оркестрының скрипкачы-концертмейстеры, 1885–1906 да хосусый опера труппаларында дирижёр, ш.и. Казан, Саратов опера ширкәтләрендә баш дирижёр (1901–03). 1906–33 тә Зур театр дирижёры, бер үк вакытта, 1924–25 тә, К.С.Станиславский опера студиясендә музыка бүлеге җитәкчесе, 1927–33 тә К.С.Станиславский исем. Опера театрының баш дирижёры. Бер үк вакытта, 1924–25 тә, Мәскәү консерваториясе профессоры (оркестр классын алып бара), 1926–29 да Мәскәү филармониясендә дирижёр. С. Россия муз. культурасы һәм театр сәнгате үсешенә бик зур өлеш кертә (Зур театр сәхнәсендә Көнбатыш Европа әсәрләре һәм рус опера классикасы буенча аеруча әһәмиятле спектакльләр). Даими рәвештә концерт эшчәнлеге алып бара, 1880 нең ахыры — 1930 ның башында Казанда еш кына чыгышлар ясый. «Урман патшасы» («Лесной царь») операсы, романслар, симф. оркестр һәм камера ансамбле өчен иҗат ителгән әсәрләр авторы.

*Әд.:* Р е м е з о в И.И. В.И.Сук. М.–Л., 1951.

**СУКАЕ́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама арьягында, Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 15,3 *км*, бассейнының мәйданы 86 *км*². Азнакай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Банки-Сукаеш авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы — Тымытык авылыннан 4 *км* төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 220 *м*, тамагыныкы — 81 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. С.ның 1,7 һәм 7 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,28 *км/км*². Туенуы катнаш, яртысыннан артыгы кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле зур түгел, фәкать 0,1 *л/с·км*² тәшкил итә. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы, җәен нык саегуы б-н характерлана. Коры елларда елганың түбән агымы кибә һәм су тамагына кадәр барып җитми. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 122 *мм*, ташу агымы катламы 65 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**СУКНО́**, к. *Өйдә тукылган постау.*

**СУКСУ́Н РАЙОНЫ́**, *Пермь краеның* көньяк-көнчыгышында урнашкан. 1924 елда оештырыла. Мәйданы — 1,7 мең *км*². Үзәге — шәһәр тибындагы Суксун посёлогы (Пермьнән 145 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 19760 кеше (2013), татарлар — 1543 кеше (2010). 1998 дән Татар үзәге эшли. Районда *Сабан туе, Нәүрүз, Ураза бәйрәме, Корбан бәйрәме* үткәрелә. Милли көрәш буенча край чемпионаты оештырыла.

**СУКЫ́Р ӘРЛӘННӘ́Р** (Ellobius), әрләнсыманнар семьялыгыннан имезүчеләр ыругы. 4 төре билгеле, Евразиянең урман-дала, дала һәм ярымчүлләрендә таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади С.ә. (E.talpinus), нигездә, Кама арьягында очрый. Елга үзәннәрендәге далаланган участокларда, ерым битләрендә яши. Гәүдәсенең озынлыгы 13 *см* га җитә, койрыгы 0,5–2,2 *см*. Күзләре бик кечкенә. Колак яфраклары юк, өске һәм аскы кискеч тешләре, үзара очлы почмак ясап, нык кына алга чыгып тора. Мехы бик йомшак. Өсте кара-коңгырт, корсагы аксыл, ян-яклары көрән-сары төстә. Җир астында яши, өскә сирәк чыга. Җир өстендә ярымай формасындагы туфрак өемнәре калдырып, катлаулы юл системалары төзи. Үсемлекләрнең тамырлары, тамырча һәм суганчалары б-н тукланa, яшелчәләрне, кавын-карбыз-кабакларны зарарлый. Ана затлар елга ике тапкыр 3–5 бала китерә.

**СУКЫ́Р КАДЫ́Ш**, к. *Сокуры*, Лаеш р-ны.

**СУКЫ́Р КАНДАЛАЛА́Р** (Miridae), кандалалар семьялыгы. Гәүдәләренең озынлыгы 2–11 *мм*. Кагыйдә буларак, гади, күзләре юк (исеме шуннан). Тәне йомшак япмалы. Төрле төстә, күпчелегe яшел. Дөнья фаунасында 6 меңнән артык төр исәпләнелә (төрләр саны буенча кандалалар семьялыгында иң бае); Россиядә 800 дән артык, Татарстан терр-ясендә 100 гә якын төре билгеле. Үсемлекләр б-н туенучы формалары өстенлек итә, кайберләре аерым бер үсемлек согы б-н туенуга махсуслашкан. Күкәйләрен үсемлекләрнең сабакларына һәм яфракларына сала. Күп кенә төрләрнең күкәйләре һәм сирәк кенә олы затлар кышлый. Кайберләре елга бер буын бирергә мөмкин. С.к.ның күбесе а.х. үсемлекләрен, мәс. чөгендер кандаласы (Polymerus cognatus) чөгендергә, люцерна кандаласы (Adelphocoris lineolatus) кузаклыларга зарар китерә.

*С.М.Шәфигуллина.*

**СУКЫ́Р КЫЧЫТКА́Н** (Leonurus), иренчәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 15 кә якын төре билгеле, Евразиянең уртача поясында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар. Биш бүлемле С.к. (L. quinquelobatus), күгелҗем С.к. (L. glaucescens) Көнчыгыш Кама арьягында һәм Көнбатыш Кама алдында очрыйлар. Ташландык урыннарда, чүплекләрдә, ерымнарда, юл буйларында, сулык ярлары буенда үсәләр. 30–100 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлекләр. Сабагы дүрт кырлы, туры, тармаклы, соры төкчәләр б-н капланган. Аскы яфраклары бармаксыман-теленмә, өскеләре — өчәр калаксыман. Чәчәкләре вак, аксыл-шәмәхә яки тонык алсу төстә, ике иренле, өске яфраклар куентыгында божрага җыйналган. Җимеше — өч кырлы чикләвекчек. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Җир өсте өлешендә флавоноид, гликозид, сапонин, алкалоид, дуплау матдәләре бар. Ике төре дә тынычландыру җыелмалары составына керә. Баллы үсемлекләр.



Биш бүлем яфраклы сукыр кычыткан.

**СУКЫ́Р ТЫЧКАННА́Р** (Talpa), бөҗәк ашаучылар отрядындагы сукыр тычкансыманнар семьялыгыннан имезүчеләр ыругы. 12 төре билгеле, Евразиядә һәм Төньяк Африкада таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — гади яки Европа сукыр тычканы (T. europaea) респ-каның барлык терр-ясендә очрый. Урманнарда, болын, кырларда, яшелчә, җиләк-җимеш бакчаларында яши. Җир асты хайваны. Гәүдәсенең озынлыгы 15 *см* га кадәр, авырлыгы 100 *г* чамасы. Гәүдәсе зур, йомры, башы сузынкы, өскә таба кысылган, муены кыска, көчле. Колаклары тышкы колак яфракларысыз, әмма ишетү аппаратын һәм күзләрен каплаучы тире җыерчыгы бар. Алгы очлыклары кыска һәм көчле, көрәксыман, җир асты юллары казу өчен җайлашкан. Койрыгы юан, зур түгел, тәңкәчекләре күренеп тора. Аяк табаны һәм борынынның кала, бөтен гәүдәсе бәрхетсыман куе йон б-н капланган, оясында хәрәкәтләнгәндә С.т.ның йоны теләсә нинди юнәлештә ята. Елга 3 тапкыр йон алыштыра: язын (йоны тулысынча алышына), җәен (өлешчә), көзен (куе, озын йон үсә). Тар җир асты юлларында артка да, алга да иркен хәрәкәтләнә. С.т.ның оясы яфрак, үлән һәм мүк түшәлгән өннән, катлаулы юллар системасыннан гыйбарәт. 100 *м*² *га* 40–70 данә сукыр тычкан оясы туры килә. С.т., нигездә, яңгыр суалчаннары, бөҗәкләр һәм аларның личинкалары, моллюсклар, үрмәкүчләр б-н туклана. Кышкы йокыга талмыйлар. Елга бер тапкыр үрчиләр. Язын парлашалар, чагыштырмача 40 көннән балалары (3 тән 9 га кадәр) туа. С.т.ның санына һава шартлары: карсыз кыш (туфракның бик тирән туңуы), корылык (яңгыр суалчаннарының туфракның дымлырак катлауларына күчүе сәбәпле), яңгырлар h.б. тискәре йогынты ясый. Табигый дошманнары: көзән, ас, ябалак, елак карчыга h.б. 1930 елларда — елына 220 меңгә кадәр, 1960 елларда якынча 30 мең сукыр тычкан тиресе җитештере-

лә. Корткыч бөҗәкләрне, коңгыз личинкаларын һ.б. коңгызларны юкка чыгарып файда китерәләр. С.т.ның казу эшчәнлеге туфракның аэрациясенә һәм дымлануына булышлык итә.

**СУЛ ҺӘМ УҢ КАНАТЛА́Р**, борынгы күчмә төрки-монгол халыкларының (бәҗәнәк, кыпчак, угыз, монгол һ.б.) традицион адм.-терр. һәм гаскәри бүленеш тәртибе. Гаскәрләр тезелгәндә уң флангта — уң канат вәкилләре, сул флангта — сул канат урнаша. Уң һәм сул канат әмирләре (ханнар) дәүләтнең феодал иерархиясендә үзләренә туры килгән урынны били. Гомумкабилә җыеннарында югары хакимнең уң ягында – олы уллары һәм аларга буйсынган ыру башлыклары, сул якта кече уллары һәм алар тарафында булган ыру башлыклары урнаша. Алтын Урданың уң канаты — *Ак Урда*, сулы *Күк Урда* дип атала.

*Ә.Г.Мөхәммәдиев.*

**СУЛ ЭСЕРЛА́Р** (сул социалист-революционерлар партиясе), 1917–23 елларда Россиядә сәяси партия (1917 нең декабренә кадәр *социалист-революционерлар партиясенең* сул канаты). 1905–07 елгы Рев-ция чорында социалист-революционерлар партиясе ике агымга бүленә: сул — «эсер-максималистлар» һәм уң — «халык социалистлары». Беренче бөтендөнья сугышы елларында «оборончылар», «центристлар» һәм сул «эсер-интернационалистлар» аерылып чыга. 1917 нең Февр. рев-циясеннән соң сул эсерлар «Земля и воля» г-тасы тирәсендә берләшә. С.э. партиясе җитәкчеләре — Б.Д.Камков, М.А.Спиридонова һ.б. Эсерлар партиясенең таркалу сәбәбе социаль борылышның характерын, хәрәкәт көчләрен һәм перспективаларын бәяләү һәм әлеге борылышта эсерлар партиясе ролен билгеләү мәсьәләләре буенча фикер каршылыгыннан гыйбарәт була. С.э. Россияне коткарып калуны кичектергесез социализмга баруда күрә, шул ук вакытта төп юнәлеш Россиядә соц. рев-ция җиңеп чыгу өчен кирәкле шартлар булдыручы дөнья рев-циясенә ясала. Алар Вакытлы хөкүмәттә кадетлар б-н коалиция төзүгә каршы булалар, бертөрле соц. хөкүмәт оештыруны, сугышны туктату, алпавытлар җирләрен бу мәсьәләне Учредительләр җыенында хәл иткәнче җир ком-тларына күчерүне хуплыйлар. Язын Гельсингфорс, Харьков, Казан һ.б. шәһәрләрдә беренче мөстәкыйль оешмалар барлыкка килә. 1917 елгы Окт. кораллы күтәрелешенә әзерләнү чорында кайбер С.э. вакытлы революцион ком-тлар составына керәләр. Окт. рев-циясеннән соң С.э.ның Үзәк бюросы оеша, ул С.э.ның бөтенсоюз конференциясен чакыру башлангычы б-н чыга. 1917 нең 19–28 ноябрендә партиянең Оештыру съезды була, анда партия уставы проекты кабул ителә, ҮК сайлана (15 әгъза һәм әгъзалыкка 15 кандидат). 1918 нең мартына кадәр партия большевиклар б-н беррәттән совет хакимияте органнарын формалаштыруда катнаша. 4 нче Бөтенроссия Советлар съездында большевикларның Германия б-н Брест-Литва солых килешүенә (1918 нең 3 марты) кул куюыннан соң С.э., большевиклар дөнья рев-циясе эшенә хыянәт иттеләр, дип белдереп, хөкүмәттән үз халык комиссарларын чакыру турында игълан итәләр. Шуннан соң партиянең иң радикаль әгъзалары карары б-н С.э.ның баш хәрби штабы, ш.у. террорлык актлары оештыру һәм уздыру өчен Бөтенроссия, Мәскәү, Петроград хәрби оешмалары оеша. 1918 нең 17–25 апрелендә Мәскәүдә партиянең 2 нче съезды уза, анда аның социаль рев-циянең төп принципларын — респ-калар советы федерациясе төзү, идарәне үзәкләштермәү, җитештерүне синдикализацияләү, «җирне социальләштерү»не раслаган сәяси программасы кабул ителә. Съезд дөнья рев-циясен тизләтү өчен халыкара террорның башлануын санкцияли. 1918 нең 28 июнендә Мәскәүдә 3 нче съезд уза, ул хакимиятне тулысынча хезмәт ияләре Советларына тапшыру, ХКСны бетерү турында белдерә. 1918 нең 6 июлендә С.э. партиясе әгъзалары тарафыннан Германия илчесе В.Мирбах үтерелә, Бөтенроссия гадәттән тыш комиссиясенең кайбер җитәкчеләре кулга алына, Мәскәү, Рыбинск, Ярославль һ.б. шәһәрләрдә фетнә күтәрү омтылышы була (тиздән ул бастырыла). Оешма әчтән таркала: С.э.ның бер өлеше террорны дәвам итү ягында була, бер өлеше большевиклар позициясенә күчә.

Социалист-революционерлар партиясенең Казан оешмасында сул агым Беренче бөтендөнья сугышы вакытында үзен күрсәтә: сугышка каршы эшчәнлек нигезендә «Коалиция комитеты» барлыкка килә, аңа Казан большевиклары б-н беррәттән сул «эсер-интернационалистлар» В.П.*Брауде*, Н.П.Пономарёв, А.И.Попов, Е.Разумова, В.Чернышёв, Д.Шляпников, К.Шнуровский һ.б. керә. Казандагы эсерлар оешмасында С.э. позициясе алга таба да көчле була. С.э. партиясе Казан ком-ты социалист-революционерлар партиясенең Казан оешмасы таркалгач барлыкка килә (1917 нең марты). Әйдәп йөрүчеләре: А.Л.*Колегаев*, И.А.*Майоров*, Н.Д.Ефремов, В.И.Мохов, В.П.Брауде, К.Шнуровский, А.И.Попов, Н.П.Пономарёв, В.Жилинский һ.б. Партия ҮК тарафыннан Казанның сул һәм уң эсерларын берләштерү омтылышы була: моның өчен 1917 нең августында эсерлар партиясе ҮК әгъзасы В.Г.Архангельский килә. Тик, берләштерелгән ком-т оештыруга карамастан (аңа 7 сул һәм 5 уң эсер керә), оешмалар бер-берсеннән бәйсез рәвештә яши. С.э. ком-ты Проломная һәм Университет (хәзер Бауман ур., 47) урамнары чатындагы Ключников йортында урнаша. Партиянең бүлекчәләре Чистай (Чистай шәһәрендә һәм өч волостьта), Спас (50 гә якын С.э.), Лаеш (100 гә якын кеше) өязләрендә дә була. Сул һәм уң эсерлар арасында төп фикер каршылыгы җир, хакимият һәм сугыш мәсьәләләрендә күзәтелә, социалист-революционерлар партиясенең Казан губерна конференциясендә (1917 нең 7 мае) һәм Крәстиян депутатларының губерна советы җыенында (1917 нең 13 мае) С.э.ның Учредительләр җыены чакырылышына кадәр җирне крәстияннәргә бирү турындагы резолюциясе кабул ителә. Монда Казан губерна крәстияннәр депутатлары Советын җитәкләгән А.Л.Колегаев зур роль уйный. Хакимият мәсьәләсендә С.э. аны советларга тапшыру ягында була (үзләре еш кына Вакытлы хакимиятне яклаcалар да), сугыш мәсьәләсенә килгәндә — аны тизрәк туктату ягында торалар. Казан губернасы буенча Учредительләр җыенына сайлауларга С.э. өчен 180 меңнән артык сайлаучы тавыш бирә (эсерлар партиясе барлыгы губернада 270 мең тавышка ия була). 1917 нең Февр. рев-циясеннән соң С.э.ның татар оешмалары оеша башлый. 1917 нең 30 мартыннан Г.Г.*Ибраһимов* редакциясендә Уфа шәһәрендә татар С.э.ның «Ирек» г-тасы нәшер ителә. 2 нче Бөтенроссия мөселман съезды (Казан, 1917 нең мае) барганда, делегатларның бер өлеше С.э. фракциясенә берләшә, ул алга таба С.э.ның татар партиясен оештыру башлангычы б-н чыга, аның төп максаты «бөтен Россиядә бүлгәләнеп беткән демократик көчләрне берләштерү, татар революционерларының бердәм органын булдыру»дан гыйбарәт була. Татар С.э.ы С.э.ның Россия оешмасын яклый. 1917 нең августында Уфада составында Г.Г.Ибраһимов, Ш.Х.*Сунчәләй*, Ф.Сәйфи, И.Рәмиев, М.Әхмәтов, Г.Әминов һ.б. булган вакытлы ҮК төзелә. *Мөселман социалистлар комитетлары* каршында башында Ш.Әхмәдиев һәм Х.Мөхетдинов торган С.э. фракциясе эшләп килә. Илче В.Мирбах үтерелгәч, татар С.э.ы террорны гаепләп чыгышлар ясыйлар һәм үз Уставларын булдыралар. С.э.ның Россия оешмасыннан аермалы буларак, татар эсерлары икмәк монополиясен таныйлар һәм ярлылар ком-тлары оештыруга каршы чыкмыйлар. С.э.ның гомумроссия оешмасы вәкилләре совет хакимиятенең барлык органнарыннан чыккач, татар С.э.ы *Эчке Россия мөселманнары эшләре комиссариаты* составында кала һәм большевиклар б-н хезмәттәшлеген дәвам итә. Алга таба татар эсерлары арасында 3 агым барлыкка килә: беренчесенең вәкилләре большевиклар б-н, икенчесенеке эсер-террористлардан аерылып чыккан эсерлар б-н кушылуны, өченчеләре С.э.ның мөстәкыйль татар оешмасын саклауны яклый. 1918 нең июнендә мөселман социалистлар ком-тлары 2 мөстәкыйль оешмага — большевикларга һәм С.э.га таркала. Алга таба күп кенә татар С.э.ы большевиклар партиясенә күчә. С.э. Казанда Окт. кораллы күтәрелешендә катнаша, Вакытлы революцион ком-тка, Казан Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советына, Казан Совет Эшче-Крәстияннәр Респ-касы ХКСна керәләр. 1918 нең Брест-Литва солых килешүенә каршы чыгыш ясыйлар. 1918 нең 22 маенда С.э. партиясенең 1 нче Казан губерна конференциясе була, аның эшендә 33 делегат, ш.и. партиянең ҮК әгъзалары А.Л.Колегаев, И.А.Майоров катнаша. Партиянең Казан губерна ком-ты сайлана. Кабул ителгән резолюциядә С.э.ның большевиклар һәм Октябрь түнтәрелеше яклы башка партияләр б-н хезмәттәшлекне яклавы билгеләп үтелә. Әмма чынлыкта, яңа хакимият идарәсе структурасында булсалар да, С.э. большевикларны һәрвакытта да якламыйлар. 1918 нең язында Казан эшче, солдат һәм крәстиян депутатла-

ры губерна советының азык-төлек бүлеге комиссары И.И.Штуцер (С.э. партиясендә тора) большевикларның азык-төлек диктатурасы турындагы декретын гамәлгә ашыруга аяк чала, ярлылар ком-тлары оештыруга да С.э. көчле каршылык күрсәтәләр. С.э. фетнәсеннән соң (1918 нең 6–7 июле) С.э. партиясенең Казандагы вәкилләре җитәкче урыннардан төшерелә, бер өлеше репрессияләнә (И.А.Майоров һ.б.), кайберләре РКП(б)га кушыла (А.Л.Колегаев һ.б.). Партия ярымлегаль хәлгә күчә, 1923 тә аның эшчәнлеге тыела. С.э.ның Казан оешмасының матбугат органнары — *«Социалист-революционер»*, *«За землю и волю»*, *«Игенче»* г-талары.

Чыг.: Программа партии социалистов-революционеров (в общедоступном изложении). К., 1917.

*Әд.:* Хайрутдинов Р.Г. На путях к Советской Автономии: Проведение ленинской национальной политики Центральным татаро-башкирским комиссариатом в 1918–1919 гг. К., 1972; Литвин А.Л., Овруцкий Л.М. Левые эсеры: программа и тактика (некоторые вопросы). К., 1992; Литвин А.Л. Общественно-политическое движение в Поволжье: Конец XIX — начало XX в. Российская историография. К., 2003; Сыченкова А.В. Отечественная историография партии левых социалистов-революционеров: Дис. ... К., 2003.

*Л.М.Айнутдинова.*

**СУЛА́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Мишә елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 23 *км*, бассейнының мәйданы 115,9 *км*$^2$. Питрәч р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы урман массивында, Иске Шигали авылыннан 7 *км* төньяктарак, тамагы Питрәч авылыннан 2 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 57 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. С.ның 1 дән 3,6 *км* га кадәр озынлыктагы 10 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,4 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 180 *мм*, ташу агымы катламы 130 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,195 *м*$^3$*/с*. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. С. бассейнында суының гомуми күләме 1,1 млн. *м*$^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**СУЛФ**, к. *ТатЛЕФ*.

**СУЛЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Дим елгасының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 27,6 *км*, бассейнының мәйданы 211,1 *км*$^2$. Бөгелмә р-нында Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгы буйлап ага. Елга башы Надеждино авылыннан 2 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Сулы посёлогыннан 4 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Оренбург өлкәсе б-н чиктә. Елга башының абс. биеклеге 310 *м*, тамагыныкы — 155 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. С.ның 1,2 дән 9,1 *км* га кадәр озынлыктагы 14 кушылдыгы бар, иң зурлары: Липовка (8,4 *км*) һәм Солдат чишмәсе (9,1 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, якынча яртысы кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 5–10 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 152 *мм*, ташу агымы катламы 75 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,533 *м*$^3$*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. С. бассейнында суының гомуми күләме 2,4 млн. *м*$^3$ булган 3 буа бар. С.ның уңъяк ярында ландшафтлы табигать истәлеге Петровка наратлары урнашкан.

**СУЛЫ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Суша елгасының (Кама елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 16,4 *км*, бассейнының мәйданы 64,1 *км*$^2$. Балык Бистәсе р-нында ага. Елга башы Югары Тегермәнлек авылыннан 4 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Күгәрчен авылының көньяк чигендә. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 60 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. С.ның 0,8 дән 5,7 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,49 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 124 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,053 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. С. бассейнында суының гомуми күләме 0,8 млн. *м*$^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**СУЛЫ́** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 34 *км* көньяктарак, Оренбург өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 3 кеше (татарлар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Баулы волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1926 да — 142, 1938 дә — 208, 1949 да — 200, 1958 дә — 122, 1970 тә — 103, 1979 да — 35, 1989 да — 6, 2002 дә — 3 кеше.

**СУЛЫ́** посёлогы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 18 *км* көньяктарак, Сулы елгасының (Димнең сул кушылдыгы) югары агымы буенда. 2010 елда 65 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1740 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Верхосулье, Богоявленский исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Богоявление чиркәве (1806 да алпавыт В.П.Рычков иганәсенә төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе, 2 тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 240 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Богоявление волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 986, 1889 да — 590, 1910 да — 539, 1920 дә — 610, 1926 һәм 1938 дә — 562 шәр, 1949 да — 417, 1958 дә — 269, 1970 тә — 197, 1979 да — 127, 1989 да — 73, 2002 дә — 81 кеше.

**СУ́ЛЬВА** (чын фамилиясе Кугушева) Мәрьям Гыйльман кызы (20.8.1901, Сембер губ. Буа ш. — 3.11.1966, Казан), драма актрисасы, ТАССРның атказ. артисты (1944). Сәхнә эшчәнлеген Гражданнар сугышы елларында фронттагы татар театры труппаларының берсендә башлап җибәрә. 1921–50 елларда һәм 1954 тән Татар акад. театры актрисасы, 1951–54 тә Респ-ка күчмә театрында эшли. Игътибарны җәлеп итәрлек матур тышкы кыяфәткә ия С., башлыча, аналар, карчыклар, хезмәтчеләр кебек характерлы рольләр башкара, тормышчан, ышандырырлык образлар иҗат итә. Аның Заһидә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Мәйсәрә («Мәйсәрә хәйләләре», Хәмзә), Гөлҗиһан («Чын мәхәббәт», Т.Гыйззәт), Феклуша, Шаблова («Яшенле яңгыр», «Кичеккән мәхәббәт», А.Н.Островский), Харитонова («Диңгездәгеләр өчен», Б.А.Лавренёв) рольләре психол. яктан ышандырырлык булулары, характерга төшенү тирәнлеге б-н аерылып тора. Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар» пьесасы буенча куелган спектакльдә ул тудырган солдат хатыны Гайнавал образы — аеруча ихтирамга лаек рольләреннән берсе. С. башкаруында ул символик образ дәрәҗәсенә җитә.

*Әд.:* Иляловa И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; шул ук. Театр имени Камала. К., 1986.

*И.И.Иляловa.*

**СУЛЬДИ́Н** Альберт Валентинович (11.11.1928, Казан — 4.1.1996, шунда ук), математик, физика-матем. фән. д-ры (1969), проф. (1972), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1979). 1951 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тының ихтималлык теориясе һәм матем. стат. бүлеге мөдире (1960–63), гамәли математика каф. мөдире (1963–91), шул ук кафедраның профессоры (1991 дән), үз тырышлыгы б-н ачылган хисаплау математикасы һәм кибернетика ф-ты деканы (1978–87). Хезмәтләре стохастик интеграллаштыруга, функцияләр якынчалыгы теориясенә, Ли алгебраларына, интеграл һәм чыгарылмалар исәпләү өчен якынчалы формулалар төзүнең ихтималый алымнарын эшләүгә карый. С. функциональ (ш.и. дифференциаль) тигезләмәләрнең чишелешләрен төзү өчен төрүче Гильберт фә-

засы төшенчәсен кертә һәм аны өйрәнә. «Известия вузов. Математика» ж-лының җаваплы мөхәррире (1979–92). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Мера Винера и её приложения к приближённым методам // Изв. вузов. Математика. 1959. № 6; 1960. № 5; Метод регрессии в теории приближений // Уч. зап. Казан ун-та. 1963. Т. 123, кн.6; Система разделения времени. К., 1973; Задачи вузовской математической науки // Изв. вузов. Математика. 1987. № 7.

**СУ́ЛЬДИНА** Галина Алексеевна (23.8.1962, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2001), проф. (2004). 1984 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 2002 дән дәүләт һәм муниципаль идарә каф. мөдире. Хезмәтләре дәүләт һәм муниципаль идарә системасының җәмгыятьтәге социаль-икътисади процессларга йогынтысы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Формирование распределительного механизма на основе системы бюджетирования. К., 2000; Стратегия развития Казани до 2015 года. СПб., 2003 (автордаш); Отношения собственности в экономическом развитии. К., 2007 (автордаш).

**СУЛЬКЕ́ВИЧ** Александр Александрович (8.12.1867, Сувалкск губ. Татар Скирсобли а. — 18.9.1916), Польша милли-азатлык хәрәкәте эшлеклесе; Ю.Пилсудский көрәштәше. Польша-Литва татарларыннан. 1890 елдан Владиславов шәһәрендә, соңыннан Кибарты посадында (Сувалкск губ.) таможня конторасында эшли. 1892 дә Парижда поляк социалистлары съездында катнаша, съездда Польша социалистлар партиясе оештырыла. Берничә тапкыр партиянең ҮК әгъзасы булып сайлана. 1900 дә Ю.Пилсудский кулга алынганнан соң, фикердәшләре б-н бергә аның С.-Петербургтагы Николай Чудотворец госпиталеннән качуын оештыра. 1905–07 дәге рев-циядә катнаша. 1906 да Польша социалистлар партиясе таркалганнан соң, аның уң канатына кушыла. Соңыннан Австро-Венгриядә эмиграциядә яши. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, Австро-Венгрия армиясе каршындагы поляк легионерлары бригадасының 5 нче пехота полкы сафларына баса. Волынь төбәгендә барган сугышларда һәлак була. 1935 тә аның җәсәде Варшавадагы Повонзск зиратына күчерелә.

*Я.Я.Гришин.*

**СУЛЬКЕ́ВИЧ** Мацей Александрович (Сөләйман Сулькевич) (20.7.1865, Вильна губ., нәселдән килгән Кәмәйшә утары — 1920, Баку), хәрби, дәүләт эшлеклесе, генерал-лейтенант (1915). Польша-Литва татарларыннан. Михаил кадет корпусын (Воронеж ш., 1883), Михаил артиллерия уч-щесен (С.-Петербург, 1886), Ген. штабның Николай академиясен (С.-Петербург, 1894) тәмамлый. Артиллерия уч-щесен тәмамлаганнан соң, рус армиясенең 6 нчы артиллерия бригадасында хезмәт итә. 1895–1903 тә — 34 нче пехота дивизиясе штабының өлкән адъютанты; 8 нче армия корпусы штабының махсус вазифалар башкаручы обер-офицеры, өлкән адъютанты, Одесса Хәрби округы штабы өлкән адъютанты, Кытай походында катнаша (1900–01), Очаков крепосте штабы башлыгы, Одесса Хәрби округы штабы каршында махсус вазифалар башкаручы штаб-офицер. 1903–05 тә 15 нче пехота дивизиясе штабы башлыгы, полковник (1903). Рус-япон сугышында (1904–05), Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1905–10 да 57 нче Модлин пехота полкы командиры. Генерал-майор (1910). 1910–12 дә Иркутск Хәрби округы штабының генерал-квартирмейстеры. 1912–17 дә 7 нче армия корпусы штабы башлыгы, пехота дивизиясе, 37 нче армия корпусы командиры. Окт. рев-циясеннән соң 1 нче аерым мөселман корпусы командиры (Яссы шәһәрендә оештырыла), корпус Хәрби Шура карары буенча (Бөтенроссия мөселман хәрби советы), җирле мөселманнарга ярдәм күрсәтү өчен, Кырымга китәргә тиеш була. 1918 нең язында немец командованиесе боерыгы буенча корпус корарсызландырыла. Офицерлар төркеме б-н Кырымга килеп җиткән С. 1918 нең июнендә Кырым өлкәсе хөкүмәтен төзи, бер үк вакытта премьер-министр, хәрби министр һәм эчке эшләр министры постларын били. 1918 нең ноябрендә С. хакимиятне Кырымның яңа хөкүмәтенә тапшыра. 1919–20 дә Әзәрбайҗан армиясенең Ген. штаб башлыгы. Әзәрбайҗанга Кызыл Армия частьлары килеп кергәннән соң, кулга алына һәм атыла. «Батырлык өчен» дип язылган алтын корал, 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г р и ш и н Я.Я., Ш а р а ф у т д и н о в Д.Р. На службе Родине. К., 2005.

**СУМ,** 1) түләү чарасы сыйфатында кулланылган алтын, көмеш, бронза коелмалар. Беренче мәртәбә *Мәхмүд Кашгари* (9 йөз) сүзлегендә телгә алыналар. Идел буенда һәм Кама алдында 7–14 йөзләргә нисбәтле берничә С.нар хәзинәсе табыла. Алар арасында — 9–10 йөзләргә караган мәгълүм бронза С.нар хәзинәсе (Болгар шәһәре): өч кырлы кисәкләр рәвешендәге калынлыгы 1 *см* га якын, озынлыгы 18 *см* һәм авырлыгы 106 *г* лы (4 бронза С.ның авырлыгы 426 *г* лы 1 драхмага тигез була) коелмалар; Урал көмешеннән эшләнгән 9–12 йөзләргә нисбәтле түгәрәк көмеш С.нар — балышлар хәзинәсе (рус елъязмаларында «Кама аръягы көмеше» буларак теркәлгәннәр), ш.у. 13–14 йөзгә караган өч кырлы озынча көмеш С.нар хәзинәсе. Идел буеннан кала көмеш С.нар хәзинәләре ш.у. Кырымда һәм элекке Мәскәү кенәзлеге терр-ясендә табыла. Көмеш С.ның авырлыгы 204,75 *г* яки 0,5 фунт тәшкил итә. 2) 120 көмеш дирһәмгә тигез акча-хисап берәмлеге (14 йөздән). С.ның әһәмияте (сатып алу бәясе) акчаның билгеле бер күләменә генә түгел, аны сугу авырлыгы нормасына карап та билгеләнә. Фарсы авторы Вассаф Үзбәк хан идарә иткән чорда С.ның 6 динарга тигез булуы турында хәбәр итә. Кайбер төрки халыкларда (ш.и. татарларда) «С.» термины «рубль» төшенчәсе б-н тиңләштерелә.

*Әд.:* И л ь и н А.А. Топография кладов серебряных и золотых слитков. П., 1924; М у х а м а д и е в А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; ш у л у к. Древние монеты Поволжья. К., 1990.

*Ә.Г.Мөхәммәдиев.*

**СУМАЛА́ КУУ́ КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́**, агач сумаласын эшләп чыгару б-н бәйле кәсепчелек. Сумала куу җиргә казылган чокырлар яки казаннарда гамәлгә ашырыла. Чокырларны тыгыз балчыклы грунтта казыйлар яисә чокырның эчен балчык б-н сылыйлар. Сумала җыю өчен чокыр уртасына чокыр асты урнаштыралар, аның өстенә сумала агызу һәм аны чүпләнүдән саклау өчен каралган улаклы агач яки таш түгәрәкләр куела. Аларга чималны (нарат яки чыршы төпләре, тамырлары, яшь агачлар) дөрес өю өчен казыклар беркетелә. Чокырга 8–10 һәм аннан күбрәк куб. сажин чимал сыя. Аннары аны салам, чыбык-чабык б-н томалап яндыралар. Яну башлангач, һава керү туктасын өчен чокырны күмәләр. Сумаланы 4–7 көн буе эретәләр. Берьюлы 10 куб. сажин чималдан 20 чиләк сумала алалар. 19 йөз ахырыннан сумала җитештерү өчен сыланган чуен казанлы мич куллана башлыйлар. Бер көнгә сумала 1–3 тапкыр куыла, һәрберсеннән 1,5 пот сумала һәм скипидар алына. Казан, гадәттә, 5–8 кешедән торган артельнеке була. Казан губернасында 20 йөз башына сумала куу кәсепчелеге Царёвококшайск өязендә киң таралыш ала, кәсепчелек б-н — 1100 йорт хуҗасы, Чабаксар һәм Козьмодемьянск өязләрендә азрак — 300 гә якын йорт хуҗасы (1909) шөгыльләнә. Сумала куучыларның аз гына өлеше Казан һәм Спас өязләрендә дә кәсеп итә.

*Әд.:* Смолокурение в Царёвококшайском, Чебоксарском и Козмодемьянском уездах Казанской губернии. К., 1905; Мелкая промышленность Казанской губернии. К., 1911; Х а л и к о в Н.А. Хозяйство татар Поволжья и Урала (середина XIX — начало XX в.). К., 1995.

**СУ́МКА** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Идел елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 37 *км*, елга башыннан Раифа күленә кадәр 16,8 *км*. Бассейнының мәйданы 386,7 *км*$^2$, Раифа күленә койганда — 184,6 *км*$^2$. Яшел Үзән р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы урман массивында, Гремячий Ключ авылыннан 1 *км* көнбатыштарак, тамагы — шәһәр тибындагы Васильево посёлогының көнбатыш чигендә, Кызылъяр авылыннан көньяктарак (җәен С. түбән агымында вак күлләргә таркалып кибә, бу вакытта Раифа күленә койган урынын шартлы рәвештә елганың тамагы дип атыйлар). Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы — 53 *м* (Раифа күленә койганда 70 *м*). Урта агымы — Идел-Кама саклаулыгының Раифа участогы терр-ясендә. С. *Аккүл, Раифа күле, Ильинка күле* аша ага. Елганың түбән агымы Куйбышев сусаклагычының терәү сулары астында калган. Су җыелу мәйданының югары өлеше Пермь системасы утырма токымнарыннан торучы төп платода, түбәнге өлеше Идел буе аллювиаль террасаларында урнашкан. Аның терр-ясе, аеруча урмансыз уңъяк яры күптармаклы ерым һәм сызалар б-н бүлгәләнгән, аларның күпчелеге кәсләнгән яки куаклар б-н капланган. Урманлылыгы 70%. С.ның үзәне киң түгел, төньяк-көнчыгыштан көньяк-көнбатышка таба сузынкы. Тугае ике яклы, 70–100 *м* га кадәр киңлектә, тигез, үләнчел үсемлекләр һәм тәбәнәк куаклар б-н каплан-



Сумка елгасы.

ган. 0,3 тән 10,3 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар, иң зурысы — Сопа (уң кушылдык); Сәр-Болак (11,5 *км*) елгасы ш.у. С. бассейнына карый. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,26 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче унконлегендә башлана, бик көчле ташу күзәтелә һәм уртача 1 ай дәвам итә. Бу вакытта уртача су биеклеге якынча 2 *м* тәшкил итә (макс. — 3,2 *м*), су чыгымы 28–30 *м*$^3$*/с* ка җитә, агым тизлеге — 0,4 *м/с*. Кар күпләп эрегән вакытта, С. бассейнында суның болганчыклыгы — 7–10 *г/м*$^3$. Апрель ахыры – майда С.да су биеклеге акрынлап кими, озак вакыт яңгырлар булмаганда елга кибә, су фәкать елганың тирән урыннарында (сулы чокырларда) гына кала. Елга ноябрь башында туңа. Кыш ахырына бозның калынлыгы 50–55 *см* га җитә. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. С.ның тамак өлешендә уңъяк ярда зоол. табигать истәлеге *Сумка соры челән колониясе* урнашкан.

*О.Н.Урбанова.*

**СУ́МКА СОРЫ́ ЧЕЛӘ́Н КОЛО́НИЯСЕ**, зоол. табигать истәлеге. Куйбышев сусаклагычы Сумка култыгының көнбатыш ярында, Яшел Үзән р-нының шәһәр тибындагы Васильево посёлогына каршы урнашкан. 1983 елда билгеләнә. Мәйданы 100 *га*. Соры челәннең яшәү урыны урман массивында, ТР-да иң зурлардан исәпләнә, 1960 елллардан билгеле. Оялау урыны — карт наратлар (150–200 яшь, биеклеге 30–35 *м*). 1980 еллар башында 400 дән артык оя исәпләнә. 1990 *га*



Сумка соры челән колониясе.

колония яңа яшәү урынына (урманның көнчыгыш өлешенә, култыкка якынрак) күчә. Антропоген (ш.и. 1996 дагы урман янгыны) һәм табигый (мәс., 2000 дәге давыл) факторларга бәйле рәвештә кошлар саны кими. 2000 еллар башына оялар саны кабат торгызыла. Табигать истәлегендә амфибияләрнең 3 (кызыл корсаклы су «үгезе», буа һәм күл бакалары), рептилияләрнең 3 (җитез һәм тереләй тудыручы кәлтәләр, гади тузбаш), кошларның 36 (саз һәм болын карчыгалары, елак карчыга, кара тилгән, яр чыпчыгы), имезүчеләрнең 11 төре (ак түшле керпе, бурсык) яши.

*Әд.:* Ш а х т а р и н Г.Ю., Г а р а н и н В.И. Колония серой цапли под Казанью // Размещение и состояние гнездовий околоводных птиц на территории СССР. М., 1981.

*А.Н.Миронов, В.И.Гаранин.*

**СУ́МКАЛЫ ГӨМБӘЛӘ́Р**, к. *Аскомицетлар*.

**СУМСА́**, татар милли ризыгы. Ачы яисә төче камырдан пешереп яки кыздырып әзерләнгән бөккән. Эчлеге төрле, күбесенчә татлы түгел (ит, балык, йомырка, үпкә-бавыр һ.б.). Татлы эчлек кактан яки җиләк-җимештән ясала. С., гадәттә, бәйрәм табынына чәй ризыгы яки икенче аш буларак чыгарыла.

*Әд.:* Татарская кухня. К., 1985.

**СУНАРЧЫЛЫ́К**, кыргый җәнлекләр һәм кошларны аулау. Төбәк терр-ясендә таш, бронза һәм тимер гасырлар (Чулман, Кама, Идел-Чулман, Балахна, Волосово, Гарино-Бор, Абашево, Ананьино, Городец, Пьянобор, Имәнкискә, Ломоватово, Кушнаренко һ.б. археол. культуралар) чорында халык эшчәнлегенең бер төре. Соңрак, игенчелек, терлекчелек һ.б. кәсепчелек үсеш алуга карамастан, үз ролен саклый. Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы халкының хуҗалык тормышында (бигрәк тә җәнлек тиресе кәсепчелеге) С. аерым бер урын алып тора. Гарәп авторы әл-Мәрвази мәгълүматлары буенча, Болгар дәүләте урманнарында «кыйммәтле мехлы җәнлекләр: тиеннәр, кешләр һ.б.» очрый. А.Курбский (16 йөз) «анда кыйммәтле сусар бар, төлкеләр һ.б. җәнлекләр тиресе киемнәр тегәргә яраклы» дип билгеләп үтә. 16 йөзнең 2 яртысында — 17 йөз башында Казан һәм Зөя өязләрендә, писцовый кенәгәләр буенча, татарлар, чуашлар һәм марилар арасында таралган «кондыз әзәрләкләү» яшәп килә. 18 йөздә Казан төбәге удел крәстияннәренең бер өлеше патша сунарчылыгын тәэмин итүдә катнаша, алар патша сараена ау кошлары китерәләр (к. *Кош аулаучы крәстияннәр*). Кайбер мәгълүматлар буенча, 19 йөз ахырында Казан губрнасында 2,5 меңгә якын кәсепче аучы исәпләнә. С. объектлары тиен, куян, төлке, бөҗыр, көртлек, урман тавыгы һ.б.дан гыйбарәт була. Аучылар күбәю, С.ны контрольдә тотмау һ.б. факторлар кәсепчелек җәнлекләре һәм кошларының саны кимүгә китерә. 1868 елда Казан сунарчылык җәмгыяте оеша, аның төп максаты булып «дөрес сунарчылыкны» пропагандалау (җәнлекләрне тәртипсез рәвештә юк итүне кисәтә торган билгеле бер кагыйдәләрне үтәү) тора. «Дөрес сунарчылык» җәмгыятьләре Зөя, Лаеш һ.б. шәһәрләрдә оеша. Хәзерге вакытта С. федераль һәм респ-ка норматив актлары б-н җайга салына. Респ-каның һәвәскәр сунарчыларын ТРның сунарчылар һәм балыкчылар җәмгыяте берләштерә.

*Әд.:* Я н и ш е в с к и й Э.П. Казанское общество охоты. К., 1869; С у х а р н и к о в А.А. Охота в ТР, как подсобный промысел в крестьянском хозяйстве // Труд и хозяйство. 1923. № 3–4; Б а ш к и р о в И.С., Г р и г о р ь е в Н.Д. Очерк охотничьего промысла Татарии. К., 1931; Х а л и к о в Н.А. Хозяйство татар Поволжья. К., 1995; А л и е в И.А., Е г о р о в Л.А. Казанское общество охоты: История, люди, события. К., 2003.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**СУНДУ́РОВ** Фёдор Романович (1.11.1941, Кайбыч р-ны Өлҗан а.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1981), проф. (1983), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993), РФ югары мәктәбе атказ. хезмәткәре (2003). Казан ун-тын тәмамлый (1965). 1965–67 елларда Казанның Ленин р-ны халык мәхкәмәсе консультанты, 1967–70 тә Совет р-ны халык мәхкәмәсе халык судьясы. Бер үк вакытта, 1968 дән, Казан ун-тында: 1983–87 дә юридик ф-т деканы, 1998–2011 дә җинаять эшләре хокукы каф. мөдире. 1996 дан «Учёные записки Казанского университета» ж-лының юридик фәннәр буенча җаваплы мөхәррире. Хезмәтләре җинаять җәзасы теориясен һәм практикасын өйрәнүгә, аны үтәү, җинаять җаваплылыгын һәм җәза бирүне дифференциацияләү һәм индивидуальләштерү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Социально-психологические и правовые аспекты исправления и перевоспитания правонарушителей. К., 1976; Лишение свободы и социально-психологические предпосылки его эффективности. К., 1980; Проблемы теории уголовного наказания. К., 2003; Наказание и альтернативные меры в уголовном праве. К., 2005.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.



А.А. Супонинский.

**СУ́ПОНИНСКИЙ** Александр Анатольевич (3.4.1978, Чирмешән р-ны Шешминка а.), РФ Герое (12.3.2000), гв. өлкән сержанты. Чистай совхоз-техникумын (1998), Әлмәт нефть ин-тын (2007) тәмамлый. 1998 елдан Россия армиясендә. 2000 дә Чечня Респ-касында сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, 76 нчы гв. Чернигов һава-десант дивизиясенең 104 нче гв. парашют-десант полкында 6 нчы рота отделениесе командиры. 2000 нең 29 февраль — 1 мартында Аргун тарлавыгындагы Улус-Керт авылы (Шатой р-ны) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: десантчылар тәүлеккә якын чечен сугышчыларының өстенлекле көчләре һөҗүмен тоткарлап торалар. 2001 дән «Татнефть» АҖдә



В.С. Сурков.

куркынычсызлык идарәсе инспекторы, өлкән инспектор-инструкторы. Медальләр б-н бүләкләнә. С. исеме Әлмәт шәһәрендәге 16 нчы мәктәпкә бирелә.

**СУРКО́В** Виктор Семёнович (12.7.1926, Лаеш кантоны Архангел а.), геофизик, РФА академигы (1991; 1987 дән СССР ФА академигы; 1979 дан мөхбир әгъза), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1986). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1950), Себер нефтьгеофизика трестында (Новосибирск ш.) эшли, 1960 елдан идарәчесе; 1962 дән Себер геол., геофизика һәм минераль чимал фәнни-тикшеренү ин-тында, директор (1970 тән). Хезмәтләре тирәнлек һәм тектоник төзелешкә, Себер терр-ясенең файдалы казылмаларына карый. С. тектоник һәм тирән төзелешләр, файдалы казылмаларның барлыкка килү һәм урнашу закончалыкларын өйрәнү, методик күрсәтмәләр һәм төрле төрдәге файдалы казылмаларны алдан әйтү карталарын төзү эшләренә җитәкчелек итә һәм шәхсән үзе дә катнаша. Татарстан терр-ясендә геофизика эшләрен үткәрү өчен, аппаратлы һәм методик комплекслар эшли. РФ Дәүләт бүләге лауреаты (1994). Бөек Ватан сугышында катнаша. Окт. рев-циясе, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Западно-Сибирский бассейн. Новосиб., 1994 (автордаш); Геостатические тектонические карты раннего (докембрий и палеозой) и позднего (мезозой, кайнозой) неогея территории Сибири масштаба 1:2500000:Объяснительная зап. Новосиб., 1998 (автордаш).

**СУ́РОВКА** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 12 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Чаллы елгасы буенда. 2010 елда 385 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 60%, татарлар — 38%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышы* чорында С.дан 14 кеше Е.И.Пугачёв гаскәренә хәрби хезмәткә алына. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, 3 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1572,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Яр Чаллы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1795 тә — 410, 1870 тә — 786, 1897 дә — 848, 1913 тә — 970, 1920 дә — 872, 1926 да — 756, 1938 дә — 667, 1949 да — 310, 1958 дә — 232, 1970 тә — 207, 1979 да — 247, 1989 да — 195, 2002 дә — 264 кеше.

**СУСА́К**, к ы р л ы к к у г а (Butomus), кырлы кугачалар семьялыгыннан үсемлекләр ыругы. 2 төре билгеле, Евразиянең уртача поясында таралган. Татарстан терр-ясендә 2 төре дә очрый. Чатырлы С. (чәчәкле камыш) (B. umbellatus) — барлык районнарның сулык ярлары буенда, сай сулыкларда, уйсулыктагы сазлыкларда, сазлыклы болыннарда, кырлы куга (ситниковый сусак) (B. junceus) Түбән Кама сусаклагычы утрауларында үсә. 50–150 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлекләр. Тамырчасы калын, шуышма. Сабагы яфраксыз, түгәрәк. Тамыр яны яфраклары кыяк формасында. Чәчәкләре алсу-ак, чатыр чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — җыелма табакча. Кырлы куга шактый кечкенә булуы б-н аерыла. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыктан һәм тамырчалардан үрчи. Тамырчасында крахмал, май, сапониннар бар; төнәтмәсе халык медицинасында бәвел кудыру, какырык куптару, ялкынсынуга каршы чара буларак кулланыла. Ондатра, кондыз, су кошлары өчен азык булып тора. Декоратив, баллы үсемлек.

**СУСАКЛАГЫ́Ч**, ясалма сулык, халык хуҗалыгында файдалану максатыннан суны җыю һәм саклау өчен, гадәттә, елга үзәннәрендә суны терәү корылмалары ярдәмендә төзелә. Елга агымын сәнәгать, а.х. һәм коммуналь хуҗалыклар, гидроэнергетика, су транспорты ихтыяҗлары өчен куллану, су басуларга каршы көрәшү өчен хезмәт итә. Күпьеллык, сезонлы (яки еллык), атналык һәм тәүлеклек көйләүле С.ка аералар. С.ның су өслеге мәйданы *км²* өлешләреннән алып берничә мең *км²* га, ә күләме берничә мең *м³* тан йөзләрчә *км³* га кадәр тирбәлә. Су өслеге мәйданы 1 *км²* дан яки күләме 1 млн. *м³* тан артык булмаган С.лар, гадәттә, *буа* дип йөртелә. С.та: нормаль су биеклеге (НСБ) — барлык корылмалар яхшы хәлдә булганда плотина озак вакыт тотарга сәләтле иң югары су биеклеге; көчәйтелгән иң югары су биеклеге (ИЮСБ) — корылмаларны саклап су ташкынын җибәрү вакытында озак тотылмый торган иң югары су биеклеге; иң түбән су биеклеге (ИТСБ) — С. һәм корылмалар гадәттәгечә калырлык иң түбән су биеклеге. Үле һәм файдалы күләмнәрнең суммасы тулы күләм дип йөртелә (к. рәсемне).

Төрле елларда (19 йөз уртасыннан башлап) Идел елгасында 9 С. булдырыла, ш.и. Европада иң зурлардан булган Куйбышев сусаклагычы, аның су өслеге мәйданының 50,7% ы исә ТР терр-ясендә. Кама елгасындагы 3 сусаклагычның иң зурысы — *Түбән Кама сусаклагычы*. Ул 1978 дә Чаллы шәһәре янында Түбән Кама ГЭСы плотинасы корылгач барлыкка килә. 1957 дә Дала Зәе елгасы бассейнында ТРның көньяк-көнчыгыш районнарындагы нефть чыгару һәм сәнәгать пр-тиеләрен су б-н тәэмин итү өчен, *Карабаш сусаклагычы*, ә 1963 тә Зәй ГРЭСын су б-н техник тәэмин итү өчен, *Зәй сусаклагычы* төзелә. Авыл җирлекләрендә сугару, балык һәм су кошлары үрчетү максатыннан, ш.у. хуҗалык




Сусаклагычның төп элементлары. 1. Күтәртүгә кадәр суның иң аз вакытындагы биеклеге; 2. Күтәртүгә кадәр суның ташу вакытындагы биеклеге; 3. Нормаль су биеклеге (НСБ); 4. Ташу суы биеклеге. ИТСБ – иң түбән су биеклеге. ИЮСБ – иң югары су биеклеге.

киреәк-ярагы өчен кече елгаларда буалар коралар.

С.лар төзү елганың *гидрологик режимын* үзгәртә. Тирәнлек шактый гына арта, су алмашу берничә тапкыр кими, темп-ра һәм бозлану режимы үзгәрә. Зур С.ларның яр буе полосасында (3–10 *км* га кадәр) климатта үзгәрешләр күзәтелә (тәүлеклек һәм еллык темп-раның салмаграк үзгәрүе, һаваның югары дымлылыгы). Киңрәк урыннарда җил барлыкка китергән дулкыннарның биеклеге 3 *м* га җитеп артып та китәргә мөмкин. Кайбер химик кушылмаларның — азотлы, фосфорлы һ.б.ның концентрациясе арта. Биомассалар тизрәк барлыкка килә, суның «чәчәк атуы» күзәтелә һ.б. Флора һәм фаунаның төр составы үзгәрә. Балыкларның уылдык чәчү шартлары һәм тугай болыннарында үләннәрнең үсүе кискен төстә начарлана, кайвакыт С. төбеннән торф калкып чыгу сәбәпле, йөзеп йөрүче торф утраулары барлыкка килә. Яр буе участоклары һәм файдалы казылма чыганаклар су астында кала, еш кына сазлыкланалар, ярлар юыла (к. *Абразия*). Урнашкан икътисади, транспорт һ.б. элементләр, санитар-гигиена һәм балык промыселы шартлары үзгәрә. Шулай ук С. төбен су астында калдыру өчен әзерләргә кирәк (урманнардан чистарту, булган сәнәгать калдыкларын, тарихи ядкәрләрне чыгару һ.б.). Әһәмиятле объектларны һәм кыйммәтле а.х. җирләрен саклау өчен терр-яләрне инженерлык саклау чаралары (дамба, дренажлар корыла, яр ныгыту эшләре башкарыла һ.б.) үткәрелә.

*Әд.:* А в а к я н А.Б., Ш а р а п о в В.А. Водохранилища гидроэлектростанций СССР. М.–Л., 1977; А в а к я н А.Б., С а л т а н к и н В.П., Ш а р а п о в В.А. Водохранилища. М., 1987; Водохранилища СССР: Каталог. М., 1988.

*В.И.Мозжерин.*

**СУСАРЛА́Р** (Martes), сусарсыманнар семьялыгыннан имезүчеләр ыругы. 6 төре билгеле, Евразия һәм Төньяк Америкада таралганнар. ТР терр-ясендә 2 төре: урман сусары (M. martes) респ-каның барлык терр-ясендәге урман массивларында очрый, агач куышларында, тиен һәм зур кош ояларында яши; таш сусары (M. foina) — Идел алдында, куаклыклар арасында, ерым, сызаларда, торак пунктлар янында яши; ояларын ташлар арасында кора. Озынча, кыска аяклы, гәүдәсенең озынлыгы 35–45 *см*, койрыгы йөнтәс, 9–13 *см* озынлыкта, авырлыгы 1,6 *кг* га кадәр. Ана С. аталарына караганда кечерәк. Танавы очлы. Колаклары шактый зур, өчпочмак формасында диярлек, очында түгәрәкләнгән. Урман сусарының кышкы йоны куе, йомшак, аксыл һәм коңгырт төстә; муенында зур сары тап бар. Таш сусарының йоны тупасрак, бик куе түгел, төсе аксылрак, муенындагы тап ак төстә, аяклары бераз төкчәле, койрыгы озынрак. С. хәрәкәтчән һәм бик җитезләр, шома агач кәүсәләре буйлап үрмәли алалар. Яхшы йөзәләр. Күбесенчә эңгер-меңгердә һәм төнлә активлар. Нигездә, тычкансыман кимерүчеләр, ш.у. тиеннәр, төрле кошлар, бөҗәкләр, кайвакыт урман җиләкләре б-н тукланалар. С.ның куышу чоры июль–августта; апрель–майда 2 дән 8 гә кадәр (гадәттә, 3–5) бала китерә. Яшәвенең 2 нче елында җенси яктан җитлегә. 14–16 ел яшиләр, әмма табигый шартларда бу яшькә сирәк җитәләр. Урман сусары — лицензияле сунарчылык объекты. Таш сусары ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**СУСАРСЫМАННА́Р** (Mustelidae), ерткычлар отрядындагы имезүчеләр семьялыгы. 24 ыругны, якынча 70 төрне үз эченә ала. Евразия, Америка, Африкада таралганнар. ТР терр-ясендә 11 төре бар. Урман, бакча, кырларда, елга үзәннәрендә яши. Гәүдәсе озынча, сыгылмалы, тар өннәргә һәм ярыкларга үтү өчен яраклашкан. Аяклары кыска. Очлыклары биш бармаклы. Кайбер төрләренең койрык астында исле сыекча бүлеп чыгаручы үзенчәлекле бизләре бар. Тиресе юка куе йон б-н капланган. С. — җитез, хәрәкәтчән хайваннар, сизү органнары яхшы үскән. Җир өстендә яшәү рәвеше алып баралар (ләтчә, таш сусары, ас), оялар казыйлар (бурсык), агачлар буйлап яхшы хәрәкәтләнәләр (урман сусары), кайберләре су янында яшиләр (кама, чәшке). Вак имезүчеләр, кошлар, бакалар, ш.у. җиләкләр һ.б. б-н тукланалар. Куышу чоры июль–августта, балалары (2–10) апрель–майда туа. Яшәвенең 2 нче елында җенси яктан җитлегә. Сасы көзән, дала көзәне, Америка чәшкесе, урман сусары, бурсык — сунарчылык объекты. Таш сусары, ас, Европа чәшкесе ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**СУ́СЛОВ** Алексей Юрьевич (23.12.1974, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (2014). Казан ун-тын тәмамлый (1997). 1999 елдан Казан технол. ун-тының гуманитар фәннәр кафедрасында эшли, бер үк вакытта социотехник системалар ф-ты деканы урынбасары. Хезмәтләре эсерлар һәм с.-д. (меньшевиклар) партияләре тарихына, тарих белеме үсешенә һәм тарихи чыганакларны өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Социалистические партии в Советской России: отечественная историография. К., 2006; Социалисты-революционеры в Советской России: источники и историография. К., 2007; Российские социалисты после октября 1917 года в отечественной историографии. К., 2013.

**СУ́СЛОВА** Светлана Владимировна (30.10.1946, Ульянов ш.), этнограф, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003), тарих фән. канд. (1981). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1970). 1976–96 елларда ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1997 дән ТР ФАнең Тарих ин-тында. Хезмәтләре татар халкының киемнәре тарихын һәм гамәли бизәлеш сәнгатен өйрәнүгә карый. ТР Дәүләт бүләге «Татарлар» («Татары») монографиясен төзүдә катнашканы өчен бирелә (2001). Россия этнографлары һәм антропологлары ассоциациясе президиумы әгъзасы (2003).

Х е з м.: Женские украшения Казанских татар середины XIX — начала XX вв. М., 1980; Этнография татарского народа. К., 2004 (автордаш); История костюма тюркских народов: Этногр. исслед. татарской народной одежды. Астана, 2011.

**СУСӨЯРЛӘ́Р** (Hydrophilidae), төрлечә тукланучылар асотрядыннан коңгызлар семьялыгы. Дөнья фаунасында 2000 нән артык төре билгеле, Татарстанда — 5. 3 төркемгә бүленәләр: 1) су асты үсемлекләре буенча шуышучылар, начар йөзәләр; 2) аяклары йөзүгә җайлашкан яхшы йөзүчеләр; 3) тирестә яшәүчеләр. С.нең гәүдәсе йомыркасыман яки озынча түгәрәк, өсте — нык кабарынкы, асты яссы. Коңгызлар таркала баручы үсемлек матдәләре б-н туена. Күкәйләрен су өслегендә яки үсемлеккә беркетелгән кузыда сала, кайвакыт ана зат кузыны бүксәсендә йөртә. Личинкалары — ерткычлар. Дымлы җирдә курчакланалар. Татарстан терр-ясендә С.нең түбәндәге төрләре аеруча билгеле. Зур С. (Hydrous piceus L.) — семьялыкның иң зур вәкиле (гәүдә озынлыгы 34–47 *мм*), зәйтүнсыман-яшел төсмерле кара. Язын коңгызлар личинкаларның үсеше өчен яраклы сулыклар эзләп актив хәрәкәтләнә. Суда активлыгы түбән, күбрәк үсемлекләр буенча хәрәкәтләнә, еш кына, атм. һавасын сулау өчен, су өслегенә чыга. Личинка күбесенчә вак моллюсклар б-н туена, ш.у. балык маймычларын юк итә. ТРның Кызыл китабына кертелгән. Кече С. (Hydrophilus caraboides) 14–18 *мм* озынлыкта, кара. Яхшы йөзә. Ике төре дә агымсыз яки акрын агымлы сулыкларны өстен күрә. Сыер тизәгендә Sphaeridium scarabaeoides очрый.

*Әд.:* Определитель насекомых Европейской части СССР. М.–Л., 1965. Т. 2; Красная книга Республики Татарстан. К., 1995.

*С.М.Шәфигуллина, Н.Ш.Әхмәтҗанова.*

**СУСЫ́Л ТЕРЛЕ́К АЗЫГЫ́**, составында 70% тан артык су булган үсемлек терлек азыгы. Татарстанда С.т.а.на силос, тамыразыклар (чөгендер, шикәр чөгендере), бәрәңге, кабак, тамыразыкларның сабагы, күпьеллык терлек азыгы үләннәре (люцерна, клевер, кындырак һ.б.), берьеллык культуралар (кукуруз, көнбагыш, борчак, вика, рапс һ.б.) керә. 1 *кг* С.т.а.ның туклыклылыгы — 0,1 дән 0,3 кә кадәр азык берәмлеге. С.т.а. җиңел үзләштерелә торган углеводларга (крахмал һәм шикәр) бай, протеинга (кузаклы үләннәрдән тыш) ярлы. С.т.а. төрләрен а.х.нда барлык хайваннар яратып ашый. Аларны, нигездә, дымлы яисә силосланган килеш ашаталар. Җәйге чорда С.т.а.ннан рациональ файдалануга яшел конвейер оештыру юлы б-н ирешелә.

*Әд.:* Т а м м е М.Ф. Корма и рационы кормления сельскохозяйственных животных. М., 1969; Г р и г о р ь е в Н.В. Справочник по заготовке и приготовлению кормов. К., 1980; М а л и к о в М.М. Система кормопроизводства в Республике Татарстан. К., 2002.

**СУСЫЛУ́**, к. «*Түләк*».

**СУСЫ́Н**, и р и с, к ы л ы ч у т ы (Iris), сусынчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 260 тан артык төре билгеле. Төньяк ярымшарның уртача һәм субтропик поясларында таралганнар. ТР терр-ясендә 5 төре бар. Венгр С. (I. hundarica), кәрлә С. (I. pumila) ташлы тау битләрендә үсәләр; су С.ы (сары С.) (I. pseudacorus), Себер С.ы (кылыч уты) (I. sibirica) — уйсу сазлыкларда, сазлыкланган болыннарда һәм сулык ярлары буенда; гибрид С. (I. hybrida) бакчаларда үстерелә. 100 *см* биеклектәге кыска тамырчалы үсемлек. Сабагы туры, шома. Яфраклары кыяк, ике рәтле, җилпәзәсыман таралгыда. Чәчәкләре аз чәчәкле чәчәк төрке-

мендә, сирәк кенә берле, сарыдан ачык шәмәхә, аксыл, җете кызыл шәмәхәгә кадәр. Җимеше — күп орлыклы озынча тартмачык. Май–июньдә чәчәк аталар. Орлыклары августта өлгерә. Вегетатив юл б-н һәм орлыклардан үрчи. Тамырчасында гликозид, дуплау матдәләре, органик к-талар бар. Кайбер С.ның тамырчаларыннан исле эфир мае алалар, ул медицинада һәм парфюмериядә файдаланыла. Халык медицинасында тир чыгару, какырык куптару һәм эч йомшарту чарасы буларак кулланыла. Декоратив үсемлек, гибрид С.ның 3 меңнән артык саны теркәлгән. Баллы үсемлекләр. Су С.ы, Себер С.ы ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Су сусыны.

**СУТКО́ВСКИЙ** Лев Фомич (Куприянович) (1821 — 25.12.1886, Казан), хирург, медицина д-ры (1848). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1843), шунда ук хирургия клиникасында эшли, проф. (1861), бер үк вакытта Казан хәрби госпитале хирургы. Хезмәтләре акушерлык һәм гинекологиягә карый; вакытыннан алда ясалма юл б-н бала таптыру тәҗрибәсен гомумиләштерә.

Х е з м.: Критическое сравнение Zithotomiae и Lithotripsae относительно их пользы при производстве операций камней мочевого пузыря. К., 1847.


*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1814–1904). К., 1904. Ч. 2.

**СУТЮ́ШЕВ** Кәрим Рәхим улы (1888–1918), Петропавел шәһәрендә (хәзерге Казакъстан Респ-касы) совет хакимияten урнаштыру өчен көрәш җитәкчеләренең берсе. 1917–18 елларда Эшче һәм солдат депутатларының Петропавел советы, революцион ком-ты әгъзасы. Советның сәүдә-сәнәгать бүлеге комиссары. 1918 дә Чех-словак корпусы фетнәсе вакытында һәлак була. Петропавел шәһәренең бер урамы аның исеме б-н аталган.


*Әд.:* Казахская ССР: Краткая энцикл. А.-А., 1985. Т. 1.

**СУТЮ́ШЕВ** Мәәмүн Гали улы (13.11.1906, Тубыл губ., хәзерге Казакъстан Респ-касы Петропавел ш. — 19.3.1990, Казан), театр рәссамы, ТАССРның, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957, 1977), ТАССРның халык рәссамы (1970). 1930 елда Казан сәнгать-театр техникумында, Б.Урманчеда укый. 1930–37 дә Татар эшче театрында сәхнә бизәүче, 1937 дән Татар сәнгать фондында; 1939–41 дә Татар акад. театрында рәссам-декоратор, 1944–76 да — баш рәссам. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1938).

Татар сәхнә рәссамнарыннан беренче булып, Татар акад. театрында 200 дән артык сәхнә әсәрен бизи. С.Батталның «Сынау», Ә.Фәйзинең «Тукай» спектакльләренә декорацияләрне 1939 да рәссамнар В.С.Никитин һәм П.Курбатов б-н бергә әзерли. Х.Фәтхуллинның «Күзләр» (1939), Т.Гыйззәтнең «Кыю кызлар», А.Н.Арбузовның «Таня» (икесе дә — 1940 та) әсәрләрен сәхнәгә куйганда өлгергән оста буларак чыгыш ясый. С.ның иҗат диапазоны татар классиклары һәм хәзерге заман авторларының пьесаларыннан алып рус һәм дөнья драматургиясе әсәрләренә кадәрге араны колачлый. Аның декорацияләренә, бигрәк тә гадәти җиһазлар, композицияләр һәм төсле чишелешләр б-н интерьер мохитен иҗат иткәндә, татар милли сәнгатенә хас сәнгатьчә сурәтләү чараларын куллану, спектакльләрнең тарихи чорын һәм хиссияти халәтен осталарча тапшыра белү хас. Сәхнә фәзасының техник мөмкинлекләре өлкәсендә тәҗрибәләр ясый. К.Симоновның «Көннәр һәм төннәр» («Дни и ночи») (1948), Ф.Шиллернең «Мәкер һәм мәхәббәт» («Коварство и любовь») (1950), М.Фәйзинең «Галиябану»



М.Г.Сутюшев.



М.Г.С у т ю ш е в. Ф.Шиллернең «Мәкер һәм мәхәббәт» спектакленә декорация эскизы. Кәгазь. Гуашь. 1950.

(1952), К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» (1956, 1976), Г.Камалның «Банкрот», П.Бомаршеның «Фигароның өйләнүе» («Женитьба Фигаро») (икесе дә — 1962), Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» (1966), Т.Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә» (1977), Р.Батулланың «Кичер мине, әнкәй» (1979) һ.б. әсәрләр буенча куелган спектакльләрне бизи.

Татар сәнгате һәм әдәбияты декадасы уңаеннан уздырылган ТАССРның сынлы сәнгать күргәзмәсендә (Мәскәү, 1957), респ-ка күргәзмәләрендә катнаша. Әсәрләре Мәскәүдәге А.А.Бахрушин исем. Дәүләт театр музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Татар акад. театры музеенда, Әлмәттәге Картиналар галереясында саклана. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз, Почёт билгесе орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* К у м ы с н и к о в Х. Татарский государственный академический театр имени Г.Камала. К., 1967; Макмун Галеевич Сутюшев: Буклет. К., 1980; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

**СУҮЛЧӘРЛӘ́Р**, кандалалар семьялыгы төркеме: суүлчәрләр (Gerridae), чыбыксыман суүлчәрләр (Hydrametridae), велиидлар (Veliidae). Дөнья фаунасында 300 гә якын төре исәпләнелә, аларның күбесе тропикларда; кайберләре ачык океаннарда яши. Россиянең Европа өлешендә 23, Татарстанда 3 төре билгеле. Каты япмалы С. (Gerris thoracicus) күл тибындагы сулыкларны өстен күрә. Суда яши, аның өслеге буйлап арткы һәм урта аякларында тиз шуыша, алгы аякларын корбанын эләктерү өчен куллана. Ерткычлар. Су өслегеннән очып баручы вак бөҗәкләрне аулый, җитез генә сикереп аларны тота; ш.у. дафнияләр, озынборын һ.б. бөҗәк личинкалары б-н туена, аларны исә озын хортумчыгы б-н эләктерә. Яр буе үсемлекләре арасында коры җирдә кышлый.

*Әд.:* Ж а д и н В.И., Г е р д С.В. Реки, озёра, водохранилища СССР, их фауна и флора. М., 1961; Б е й - Б и е н к о Г.Я. Общая энтомология. М., 1966; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977.

*Н.Ш.Әхмәтҗанова, С.М.Шәфигуллина.*

**СУҮСЕМНӘ́Р** (Algae), су мохитендә яшәүче түбән төзелешле үсемлекләр төркеме, кайбер төрләре туфракта һәм аның өслегендә, кыяларда, агач кәүсәләрендә һәм башка җир өсте биотопларында яшәргә җайлашканнар. С. — үсемлекләр дөньясының борынгы вәкилләре, якынча 1,5 млрд. ел элек барлыкка килгәннәр. Составында фотосинтез процессы бару өчен кирәкле пигментлары бар һәм мөстәкыйль рәвештә органик матдәләр ясарга сәләтле. Беркүзәнәкле (хлорелла, хламидомонада), колониаль (вольвокс), күпкүзәнәкле (спирогира, ламинария) организмнар. Катламадан (таллом) торалар, органнарга һәм тукымаларга бүленмиләр. Таллом барлыкка китерүче күзәнәкләр целлюлоза һәм пектин матдәләрдән торучы каты стенка б-н капланган. Күзәнәк пигментлары бер яки берничә төш һәм хроматрофлардан (пастидлар) тора. Төп туклану ысулы — автотроф, әмма гетеротроф туклану да очрый. Җенси һәм җенси булмаган (бүленеп) юл б-н үрчи. С.нең 12 бүлеге бар: зәңгәрсу-яшел, саргылт-яшел, яшел, алтынсу, алтынсу-кызыл, көрән, харалар, эвгленалар һ.б., барлыгы 30 меңгә якын төре билгеле. ТР терр-ясендә — 10 бүлек. Куйбышев сусаклагычында С.нең 1300 дән артык төре, төрчәсе һәм формасы ачыкланган. *Кремнийлы суүсемнәр* һәм зәңгәрсу-яшел суүсемнәр киң таралган. Кече елга һәм күлләр фитопланктонында төрләрнең саны сизелерлек кими, кремнийлы һәм яшел (хлорококк) С. өстенлек итә.

С. сулыкларда кислород һәм органик матдәләр хасил итүдә беренчел рольне уйныйлар, сулыклардагы бөтен хайваннар дөньясы алар исәбенә яши. Туфрак барлыкка килү процессында катнашалар. Бик нык үрчегән очракта, суның «чәчәк атуына» сәбәпче булалар, шуның аркасында балыкларга һәм башка су хайваннарына яшәү кыенлаша. С. аксым, углевод, витамин һәм микроэлементларга бай, аларның кайберләре азык продукты (мәс., хлорелла) булып тора. Ашлама, терлек азыгы буларак кулланыла. 22 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Экология фитопланктона Куйбышевского водохранилища. Л., 1989; Х а л и у л л и н а Л.Ю.,

А м о с о в Д.В. Фитопланктон охраняемых рек Казанка и Мёша // Роль особо охраняемых природных территорий в сохранении биоразнообразия: Материалы науч.-практ. конф. Чебоксары, 2000; Фитопланктон поверхностных вод Республики Татарстан // Проблемы био- и медэкологии Республики Татарстан. К., 2001. Вып. 2.

*Л.Ю.Хәлиуллина.*

**СУФИЧЫЛЫ́К ӘДӘБИЯТЫ́**, *суфичылык* идеяләре б-н сугарылган урта гасырлар гарәп, фарсы һәм төрки-татар әсәрләре җыелмасы. С.ә. суфичылык барлыкка килү б-н килеп чыга, шәркыятьче Е.Э.Бертельс фикеренчә, аның беренче үрнәкләре Басралы Рабигый әл-Адавии (713–718 арасы — 801) догаларында ук күренә башлый. Фарсы, төрки суфичылык поэзиясе 12–15 йөзләрдә чәчәк ата. С.ә.ның күренекле вәкилләре — Д.Руми, А.Ясәви, С.Бакыргани. С.ә.на, бигрәк тә суфичылык поэзиясенә традицион образларны куллану хас, мәс., Аллаһ — дөреслек, гаделлек, пакьлек, шәфкатьлелек, юмартлык һ.б. сыйфатларга ия булган абсолют идеал. Лирик һәм эпик герой аның бөеклегенә таң кала, шушы ирешә алмаслык камиллек үрнәген истә тотып, үзенең уй-теләген, эш-гамәлләрен камилләштерергә омтыла. Идеал күзлегеннән чыгып, җәмгыять, адәм балаларының кимчелекләре тәнкыйтьләнә. Геройның рухи халәтен һәм Аллаһка карата үз мөнәсәбәтен суфи шагыйрьләр катлаулы образ һәм символлар аша белдерәләр (мәс., чәчәк һәм сандугач символлары — егет б-н кыз арасындагы мәхәббәтне, мистик мәгънәдә Аллаһка бөек мәхәббәтне белдерә). Суфи шагыйрь якын кешеләрне ярату кирәклеген әйтә, ярдәмчеллеккә өнди. Суфичылык поэзиясендә фольклор элементлары файдаланыла, шигъри формалар халык җырына, притчага, могҗизалы экияткә тартым булалар. С.ә.нең күренекле вәкилләре — Мәхмүд Болгари, Мәүла Колый, Т.Ялчыгол, Ә.Каргалый, Һ.Салихов, Г.Чокрый, Ш.Зәки һ.б. татар язучылары һәм шагыйрьләре.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Б е р т е л ь с Е.Э. Избр. труды. Т. 3. Суфизм и суфийская литература. М., 1965.

*А.М.Ахунов.*

**СУФИЧЫЛЫ́К** (гарәп. تصوف суф — йон, йон тукыма; моннан — кыдан ясалган кием суфи-аскет атрибуты булып чыга; суфи — сүзгә-сүз — йон тукымадан әзерләнгән кием киюче; С. гарәп. — тәсаувыф), *исламда* мистик-аскетик агым. Кайбер Көнбатыш Европа тикшеренүчеләре 20 йөзгә кадәр «С.» атамасын грекча «sophia» (зирәклек) сүзенең мәгънәсе б-н бәйләгәннәр, кайберәүләр мәчет янәшәсендәге күперчектә яки эскәмиядә (суффа) утырган Мөхәммәд пәйгамбәрнең юлыннан баручы ярлы, тәкъва кешеләрне суфилар дип атаганнар. С. рухы *Мөхәммәд* пәйгамбәрнең кайбер сәхабәләреннән — Әбү әд-Дәрдәдә, Әбү Зәррдә һәм Хөзәйфәдә сизелә (7 йөзнең 2 нче яртысы). 8 йөз уртасында — 9 йөз башында Гыйракта һәм Сүриядә яшәгән, эсхатологик рух, байлыкка битарафлык һәм мохтаҗлыкка түземлелек сыйфатлары хас булган дәрвишләрне беренче суфилар дип санаганнар. Соңрак әлеге агым Аллаһ турындагы белемнәргә йөз тота, С.ның характерлы үзенчәлекләре формалаша: җанның үтә нечкә хәрәкәтенә, кеше гамәленең яшерен сәбәпләренә тирән анализ ясауга юнәлдерелгән антропоцентризм, шәхси кичерешләргә һәм дини хакыйкатьне эчтән кабул итүгә игътибар, Коръәнне киная б-н аңлату, сүзсез дога (тәфәккүр), догага чакыру (зикер), фәкыйрьлеккә өндәү (фәкыр), дәрвишлек (зөһедлек), социаль активлыктан баш тарту һ.б. Суфилар мөселманнарны җаннарын (нәфес) гөнаһлы һәм матди максатлардан чистарту юлына басарга, рухларын камилләштерергә өндиләр. 9–10 йөзләрдә суфилар мәктәпләре барлыкка килә, иң йогынтылыларыннан Басра (Басра ш., нигез салучысы — Хәсән әл-Басри, 742–828), Багдад (Багдад ш., — Әбү Касыйм әл-Җунайд, 830–910) һәм Хорасан (Көнчыгыш Иран — Мансур әл-Хәллаҗ, 858–922) мәктәпләре була. С.та берничә юнәлеш барлыкка килә, шулардан чиктән тыш, экстатик позициядә суфилар рухын Аллаһ б-н берләштерүче идеяләргә өндәүче әл-Бистами (874 тә вафат) һәм әл-Хәллаҗ (922 дә җәзалана) тора. С.та әл-Җунайд (910 да вафат) тарафдарлары уртачыл позициядә: алар һәрвакыт үзләренең Коръән һәм Сөннәгә бирелгәнлекләрен раслап, дәлилләп торалар: Аллаһ б-н психол. дәрәҗәдә берләшү юлын эзлиләр. Аллаһ б-н кешенең үзара мөнәсәбәтләрен шулай аңлаткан өчен, С. сөнни илаһият галимнәре тарафыннан гаепләнә. Шуңа да карамастан, 12 йөздә С.тагы әхлак нормаларының һәм гамәли элементларның кыйммәтен таныган әл-Газәли һәм Ибне Гарәби кебек зур фикер ияләренең абруйлары нәтиҗәсендә, С. исламда законлаштырыла һәм мөселман җәмгыятенең дини тормышында мөһим элементка әверелә.

12–13 йөзләрдә С. борадәрлекләре (тарика) оеша, аларның күпчелеге нигез салучыларының исемен йөртә: Сухравардия — Әбү Хәфсә әс-Сухраварди хөрмәтенә (1155–91), Әхмәдийә — Әхмәд әл-Бәдәви (1199–1276), Кадыйрийә — Габдел-Кадыйр әл-Җилани (1077–1166), Ясәвийә — Әхмәд *Ясәви* (1103–67), *Нәкышбәндийә* — Баһаветдин Нәкышбәнди (1318–89).

Рухани остаз (шәех, *ишан*) җитәкчелегендә шәкертнең (мөриднең) С. теориясен һәм практикасын үзләштерүе үсешенең башлангыч этабында мөһим элемент булып тора. Ишан остазлыкка рөхсәтне (иҗазәт) үзенең укытучысыннан алган. Ә ул исә, үз чиратында, пәйгамбәрләрдән, ш.и. Мөхәммәдтән башланып киткән күчә бару (силсилә) чылбырында бер буын булып торган. Суфилыкка ирешү юлы 4 баскычтан тора: *шәригать* — ислам кушканны тайпылусыз башкару; тарикать — мөриднең суфи ишанга карата суфичылык юлы; мәгърифәт — Аллаһны тану һәм аның б-н кушылу; Аллаһны танырга омтылучыларга илаһи вәхи; хакыйкать суфи тарафыннан хакыйкатьне мистик аңлауга ирешү. Мистик максатларга ирешү алымнары борадәрлек гамәлләренә бәйле булулары на карап аерылалар (психотехника, аутотренинг, физик күнегүләр һ.б.).

Идел буе төбәгендәге беренче суфилар Ясәвийә борадәрлек вәкилләреннән була (Алтын Урда чоры). Мөселманнар арасында С. агымы таралу биредә С.ның төрки тармагына нигез салучы Ә.Ясәвинең иҗаты һәм ислам динен тарату эшчәнлеге б-н бәйле (1103–67). Ясәвийә тәгълиматы б-н бәйле карашлар *Колшәриф, Мәүла Колый* иҗатларында да очрый. Әлеге борадәрлекнең йогынтысы 18 йөзгә кадәр саклана. Соңрак ул абруйлы шәехләрдән Мийан Фазл-әл Габд әл-Кадыйр, Хәлифә Ниязколый ибне Шаһнияз әт-Төрекмәни (Бохара ш.) һәм Фәизхан әл-Кабули (Кабул ш.) яшәгән чорда Нәкышбәндийә борадәрлеге тарафыннан кысрыклап чыгарыла яки ассимиляцияләнә. Аларның шәкертләреннән *Г.Курсави, Ә.Каргалый, Ш.Мәрҗани, Г.Утыз Имәни, М.Хөсәенов* һ.б.ны күрсәтергә була. Нәтиҗәдә Идел һәм Урал буйларында 19 йөзнең 2 нче яртысында Нәкышбәндийә кебек үк таралган мөҗәддидийәдән нәкышбәндийәнең башка тармагы — Госманлылар империясеннән килгән халидийә аерылып чыга. Идел буенда ул мөриде Г.*Баруди* булган ишан З.*Рәсүлевнең* эшчәнлеге нәтиҗәсендә таныла һәм киң таралыш ала.

Окт. рев-циясеннән соң, дәүләт тарафыннан дингә каршы актив көрәш алып барган чорда, С. традицияләре нык какшый, әмма кайбер имамнар һәм аларның эзләреннән баручылар эшчәнлекләрен дәвам итәләр. 1950 елларның 2 нче яртысында Норлат р-нының Кизләү, Самара өлкәсе Чаллыбаш р-нының Благодаровка авылларында имамнар яшәгәне; Казанда З.Рәсүлевкә бәйле суфилар җәмгыяте эшләгәне билгеле. Совет чорында ислам тәгълиматлары һәм институтлары б-н (Г.Гурҗиев, П.Сүбү, Раҗниш һ.б.) турыдан-туры бәйле булмаган яңа рухани, эзотерик С. тәгълиматлары барлыкка килә. Анда катнашучылар психотехнологияләр, транс халәтләрен, динамик медитацияләр (бию, бөтерелү) кулланып кешенең мөмкинлекләрен тикшерүне үзләренең максатлары итеп игълан итәләр. Ш.у.к. *Дәрвиш*.

*Әд.:* Б е р т е л ь с Е.Э. Избр. труды. Т. 3. Суфизм и суфийская литература. М., 1965; С т е п а н я н ц М.Т. Философские аспекты суфизма. М., 1987; Суфизм в контексте мусульманской культуры. М., 1989; Э р н с т К. Суфизм. М., 2002; М и н н у л л и н И., М и н в а л е е в А. Суфизм в Советском Татарстане // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2007. № 1; К е м п е р М. Суфии и учёные в Татарстане и Башкортостане: исламский дискурс под русским господством. К., 2008.

*А.В.Климин.*

**СУФИЯ́РОВ** Фәрит Суфияр улы (20.10.1939, Башкортстан АССРның Яңавыл р-ны Исәнбай а.), шагыйрь, Башкортстан Респ-касының атказ. мәдәният хезмәткәре (1996). Татар һәм башкорт телләрендә яза. Алабуга пед. ин-тын тәмамлый (1969). 1969–92 елларда Яңавыл районының Истәк урта мәктәбендә укыта. 1992 дән Яңавыл язучылар оешмасында җаваплы сәркәтип. Шигырьләрен «Идел» альманахында (1979), «Сахраларга сыгам» (Уфа, 1989), «Бер тауда ун чишмә» (1992) күмәк җыентыкларында бастыра. «Хәйерле иртә!» (Уфа, 1990), «Йөшлек авазы» (Уфа, 1990), «Серләремне сөйлим» (1993), «Йер генәмнең йәме» (Уфа, 1997), «Гомер язлары» (Уфа, 2002), «Күңелем

кошлары» (Уфа, 2004), «Йолдызлар җиле» (Уфа, 2007), «Хисләр ташкыны» (Уфа, 2009) шигъри җыентыклары авторы. С. поэзиясе туган җиргә, табигатькә мәхәббәт, туган халкына һәм аның рухи байлыкларына якынлык хисе б-н сугарылган. Башкортстан Респ-касының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә (2000).

**СУХА́НОВ** Идел Әхмәтгали улы (1.6.1926, Казакъстан ССР Лепсы ш.), генерал-майор (1978). Харьков хәрби авиация элемтә уч-щесен (1947), К.Е.Ворошилов исем. Рига югары инженерлар хәрби авиация уч-щесен (1959) тәмамлый. 1943 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, Урта Азия хәрби округының 125 нче запас укчы полкында рядовой. 1948–54 тә 1 нче аерым элемтә батальонында һәм СССР Хәрби Һава көчләренең җирдә самолёт йөртү эшен тәэмин итүдә: техник-инструктор, радиопеленгатор әзерләү буенча взвод командиры, станция-эксплуатация хезмәте башлыгы, радиоактырту маягы ротасы командиры. 1959–60, 1965–74 тә Мәскәү хәрби округында: СССР Хәрби Һава көчләре авиациясендә самолётларны утырту системасы өлкән инженеры һәм башлык урынбасары. 1960–65 тә Германиядә Совет гаскәрләре төркемендә: 170 нче аерым элемтә һәм радиоактылык техникасы дивизионының техника буенча дивизион командиры урынбасары, 24 нче һава армиясенең 83 нче аерым элемтә полкында техник хезмәт башлыгы. 1974–81 дә Киев Хәрби округының 17 нче, 4 нче һава армияләре элемтә һәм радиотехника б-н тәэмин итү гаскәрләре башлыгы. Киевта яши. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**СУХА́НОВ** Павел Павлович (18.8.1954, Казан), физик-химик, химия фән. д-ры (2003). 1976 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Бөтенсоюз физик-техник һәм радиотехник үлчәүләр фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында эшли. 1977 дән Казан технол. ун-тында. Хезмәтләре табигый һәм ясалма полимерларның физика-химиясенә карый. С. ТМР ысуллары б-н мономер, олигомер һәм полимерлар кергән композицияләрдә структуралар барлыкка килү кинетикасын һәм механизмнарын тикшерә. Полисульфидлы олигомерларны сәнәгый металл диоксидлары б-н ачытуның ион-радикаллы механизмын эшли. Акрил к-талары һәм лактам катнашмалары нигезендәге полимер системаларның бу ике мономер катнашында акрил к-таларының радикаллы полимерлашуы һәм ион табигатьле химик процесслар фонында формалашуын ачыклый. Олигомер макромолекулаларның тармаклану һәм соңрак челтәр рәвешенә керү процесслары арасындагы бәйлелекнең топологик кына түгел, ә структур-динамик та булуын күрсәтә; макромолекуляр системаның дискретлык параметрын кулланып, аны гадиләштереп топологик характерлау методикасын тәкъдим итә. Золь-гель күчешләр өлкәсендә барган макромолекуляр реакцияләр үзенчәлеген сурәтләү өчен, кайтма булмаган чылбырара алмашу моделен эшли. Гетерочылбырлы олигомерларда структурлашу механизмнары б-н макромолекуляр ансамбль төзелү процесслары арасындагы бәйлелекне ачыклый. Полимерның аморф фазасын формалаштыру моделен тәкъдим итә, биредә үзәк урынны «макросегмент» — бирелгән фазаның полимер материал составындагы макроскопик үзлекләр комплексын чагылдыра торган минималь (элементар) күләме алып тора. ТМР алымнары б-н микроб популяцияләренең һәм модельле кушылмаларның (ферментлар, фосфолипидлар) физик-химик табигатьле төрле факторлар (үтә югары ешлыклы электромагнит нурланыш) һәм комплекс ясагычлар (комплексоннар, каликсареннар) тәэсиренә адаптив җавап механизмнарын тикшерә, модификацияләнгән полиолефин композицияләрдә структура-фаза әверелешләрен анализлау методикасын тәкъдим итә.

Х е з м.: Модификация герметиков на основе полисульфидных олигомеров // Высокомолекулярные соединения. 1989. Т. 31А, № 2 (автордаш); О механизме вулканизации полисульфидных олигомеров диоксидами металлов // Каучук и резина. 1991. № 9 (автордаш); Процессы структурирования в гетероцепных олигомерах: Анализ методами ЯМР. К., 2005; Полимерная тара и упаковка: Введение в физикохимию полимеров. К., 2006 (автордаш).

**СУ́ХАРЕВО** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 23 *км* көньяк-көнбатыштарак, Түбән Кама — Кама Аланы автомобиль юлы буенда. 2010 елда 712 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 62%, татарлар — 27%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Богородский, Тюремное Городище исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Казан Богородица чиркәве (1761 дә алпавыт Н.Сухарев салдырган чиркәү 1891 дә яна, аның урынына сәүдәгәр И.Г. һәм В.Г.Стахеевлар иганәсенә 1892 дә яңадан төзелә), земство мәктәбе, китапханә, фельдшерлык пункты, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 650 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Сухарево волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1834 тә — 309, 1870 тә — 907, 1897 дә — 1080, 1920 дә — 1275, 1926 да — 962, 1949 да — 739, 1958 дә — 584, 1970 тә — 702, 1979 да — 664, 1989 да — 594, 2002 дә — 729 кеше.

**СУ́ХОВ** Евгений Евгеньевич (25.7.1959, ГДР, хәзер ГФРның Потсдам ш.), палеонтолог, стратиграф, геол.-минерал. фән. д-ры (2008), язучы. Казан ун-тын тәмамлый (1983), шунда ук эшли. Хезмәтләре палеонтология, палеогеография һәм стратиграфиягә карый. С. беренче булып Пермь утырмаларының вак фораминифералары буенча Печора төбәгенең төп киселешләрен җентекле өйрәнә, Биармий палеогеогр. өлкәсе чикләрендә төбәкара чагыштыру тәкъдим итә, бу өлкәнең Пермь системасы киселешләренең микропалеонтологик сыйфатланмасын тулыландыра. Фораминифераларның яңа 2 ыругын һәм яңа 84 төрен тасвирлый. Детектив жанрдагы «Ләгънәт төшкән Русь» («Окаянная Русь», М., 1995), «Ата карак» («Медвежатник», М., 2000), «Сталинны үтерергә» («Убить Сталина», М., 2006) һ.б. романнар авторы.

Х е з м.: Записки о Казанской школе геологов. К., 1998; Местная зональность Казанского яруса стратотипической области по мелким фораминиферам // Геология и разведка. 2006. № 2.

**СУ́ХОВА** Вера Александровна (29.11.1954, Оренбург өлкәсенең Богырыслан р-ны Михайловка а.), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009). Миасс геол. тикшеренүләр техникумын тәмамлаганнан соң (1974), «Уралкварцсамоцветы» ҖБнең Үзәк-Урал геол. тикшеренүләр экспедициясендә эшли. 1988 дән «ТатНИПИнефть» ин-тында, 2002 дән «ТР Геоүзәк ДҖБ» дәүләт унитар пр-тиесендә, 2005 тән ТР ФАнең Янучан файдалы казылмаларны эзләү һәм үзләштерү проблемалары фәнни-тикшеренү үзәгендә, 2008 дән ТР ФАнең Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары ин-тында. Дәүләт бүләге Татарстан Респ-касының Көнбатыш өлешенең нефтьлелеге перспективаларын бәяләү һәм нефть чыганакларын эзләү алымнары комплексын эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**СУ́ШКА** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Актай елгасының (Идел елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 14,4 *км*, бассейнының мәйданы 106,1 *км*$^2$. Идел аръягы түбәнлегеннән, Спас р-нында ага. Елга башы Ямбакты авылыннан көньяктарак, тамагы Вожи авылыннан көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 100 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. С.ның 2,7 *км* озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,16 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 60 *мм*, ташу агымы катламы 44 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,058 *м*$^3$*/с*. Коры елларда елга, плёслы күлләр тезмәсенә таркалып, бөтен озынлыгында диярлек кибә. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. С. бассейнында суының гомуми күләме 0,8 млн. *м*$^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**СУШКО́В** Сергей Владимирович (17.6.1961, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (2006). 1983 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1986 дан Татар гума-

нитар-пед. ун-тында, халыкара элемтәләр идарәсе башлыгы (2004–06), геом. каф. профессоры (2006 дан), Казан федераль ун-тының ихтималлык теориясе һәм гравитация каф. мөдире (2012 дән). Хезмәтләре гравитация теориясенә, кара тишекләр һәм «сукыр тычкан оялары» физикасына карый. С. гравитация теориясендә «сукыр тычкан ояларын» сурәтләүче тигезләмәләрнең берничә төгәл чишелешен тапты һәм өйрәнә. Хронологик горизонт тирәсендә «сукыр тычкан оялары» булу ихтималын, квант кырларының үз-үзен тотышын тикшерә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Self-consistent wormhole solutions of semi-classical gravity // Phys. Rev. Letters. 1997. V.78 (автордаш); Completeness principle and quantum fields on nonglobally hyperbolic spacetimes // Gravitation and Cosmology. 2003. V.14; Wormholes supported by a phantom energy // Phys. Rev. D. 2005. V.71.

**СУЫКСУ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сая елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 289 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1930 елларга кадәр Салкын Чишмә исемен йөртә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тимерчелек, балта эше, башмак һәм кием тегү, ярма яру, он тарту, олаучылык, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; мәчет (1907 дә төзелә), мәктәп, земство аптекасы, тимерчелек, 5 вак-төякләр кибете була; чәршәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1824,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Салкын Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 180 ир-ат; 1859 да — 808, 1897 дә — 1120, 1908 дә — 1216, 1920 дә — 967, 1926 да — 1082, 1938 дә — 992, 1949 да — 533, 1958 дә — 403, 1970 тә — 376, 1989 да — 273, 2002 дә — 293 кеше.

**СУЫКЧИШМӘ́** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Дим елгасы буенда. 2010 елда 80 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. 1928 дә нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Баулы волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1938 дә — 335, 1949 да — 301, 1958 дә — 241, 1970 тә — 258, 1979 да — 202, 1989 да — 138, 2002 дә — 90 кеше.

**СУЫКЧИШМӘ́** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 17 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чыбыклы елгасы буенда. 2010 елда 226 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, китапханә. Мәчет. 1925 тә Чыбыклы авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оештырылган көненнән ТАССРның Чаллы кантоны Зәй волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1926 да — 250, 1938 дә — 327, 1949 да — 364, 1958 дә — 391, 1970 тә — 462, 1979 да — 311, 1989 да — 185, 2002 дә — 205 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**СУЮ́РОВ** (Сөеров) Фәрит Габдрахман улы (7.1.1939, Казан), нәкышьче, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2007). 1 нче гильдия Казан сәүдәгәрләре Сөеровлар нәселеннән. Казан сәнгать уч-щесен (1962), Чуаш пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тын тәмамлый (1969). 1967–69 елларда 3 нче балалар сәнгать мәктәбе укытучысы, 1969–84 тә 5 нче балалар сәнгать мәктәбе директоры, 1984–85 тә һәм 1986–94 тә сәнгать уч-щесе директоры, 1985–86 да Татарстан сәнгать фонды директоры (Казан). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1992). Пейзаж остасы буларак, С. майлы буяу нәкыше, пастель, акварель техникаларында эшли. Аның әсәрләренә рәссамның табигатьне күтәренке лирик-романтик рухта җанландыруы, образлы чагылдыруда төсле (җылы һәм салкын гамманың капма-каршы аралашуы) һәм фәзаи-композицияле эффектлар (үзенчәлекле ракурс) ярдәмендә хыялга бирелүе хас.

Төп әсәрләре: «Аюдаг» (1986), «Уяну» (1998), «Март» (1999), «Беренче кар» (2003), «Көзге җыр» (2007), пастельләр — «Кышкы кояш» (1998), «Кыргый алмагач» (1999), «Күл өсте», «Иллләт елгасы» (икесе дә — 2002), «Көзге моң» (2004), «Мишә елгасы» (2006), «Кичке Идел», «Идел көе. Иртә», «Мари әкияте», «Мәрҗани мәчете» (барысы да — 2007), «Зәңгәр күл», «Тукай-Кырлай» (икесе дә — 2008).

Респ-ка (1985 тән), зона — «Идел буе республикалары сәнгате» (Саранск, 2004), «Зур Идел» (1998, 2003, 2008), бөтенроссия — «РСФСРның 16 автономияле республикасы» (Мәскәү, 1971), сәнгать күргәзмәләрендә (Мәскәү, 2004) катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда (1989, 2005–06, 2009, 2014) уздырыла.

Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Голландия, Бөекбритания, Финляндия, Төркиядәге шәхси тупланмаларда саклана. ТР Мәдәният министрлыгының Б.Урманче исем. бүләге лауреаты (2009). Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ш а г е е в а Р. Путь в прекрасное далёко // Казань. 2005. № 10; ш у л у к. Вернуть искусству сакральность // Татарстан. 2009. № 1; Пейзаж Фарида Суюрова. Лирика Рената Хариса: Альбом. К., 2008.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**«СҮЗ»**, газета; к. «*Ил*».

**СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕ́**, уртак гомуми лексик-семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләренә нигезләнеп төркемләнгән сүзләр. Татар телендә мөстәкыйль һәм ярдәмлек С.т.н аерып өйрәнәләр. Мөстәкыйль С.т. мөстәкыйль лексик мәгънәгә ия, атау функциясен башкаралар, ягъни чынбарлык күренешләрен атыйлар, предмет, күренеш, билге, эш-хәлләрне белдерәләр. Мөстәкыйль С.т.нә *исем, сыйфат, фигыль, рәвеш, сан, алмашлык, аваз ияртемнәре* һәм хәбәрлек сүзләр керә. Ярдәмлек С.т. атау функциясен башкармыйлар, мөстәкыйль сүзләргә бары өстәмә мәгънәләр бирү, аларны бер-берсенә бәйләү яки модаль мәгънәләр ясау өчен хезмәт итәләр. Ярдәмлек С.т. бәйләгеч һәм модаль С.т.нә бүлеп караладар. Бәйләгеч С.т. (бәйлекләр, бәйлек сүзләр, теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләр, мөнәсәбәтле сүзләр) сүзләрне (җөмләләрне) үзара бәйләү өчен хезмәт итәләр. Модаль С.т. (*модаль сүзләр, ымлыклар* һәм *кисәкчәләр*) сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерәләр. Һәр сүз төркеменең үзенә генә хас грамматик категорияләре бар. Аларда теге яки бу сүз төркеменә карый торган барлык сүзләр өчен дә уртак гомуми мәгънә була. Мәсәлән, предметлык мәгънәсен белдерүче исем сүз төркеменә морфологик яктан — килеш, тартым, сан, хәбәрлек категорияләре; эш, хәл, хәрәкәт мәгънәсен белдерүче фигыль сүз төркеменә юнәлеш, наклонение, заман, зат-сан, дәрәҗә категорияләре хас; предметның билгесен белдерүче сыйфат сүз төркеме морфологик яктан төрләнмәве б-н аерылып тора, аңа бары тик дәрәҗә категориясе генә хас, синтаксик яктан конструктив түгел, җөмләдә күбрәк аергыч булып килә һ.б. Хәзерге тел белемендә С.т.н аерып өйрәнү мәсьәләсе бәхәсле булып кала бирә.

*Әд.:* Татар грамматикасы. Морфология. М.–К., 2002. 2 т.; Х и с а м о в а Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006; Лингвистический энциклопедический словарь. М., 1990.

*М.З.Зәкиев.*

**СҮЗ ЯСАЛЫШЫ́**, 1) Тел белемендә киң кулланылышта булган кушымчалау, сүзләр кушылу, конверсия, аббревиация (к. *Аббревиатура*) һ.б. ысуллар б-н яңа сүзләр ясалу.





Ф.Г. С у ю р о в. 1. «Зәңгәр күл». Кәгазь. Пастель. 2008; 2. «Тукай-Кырлай». Кәгазь. Пастель. 2008.

Телнең сүзлек составын тулыландыруның төп алымнарыннан берсе. Татар телендә С.я.ның берничә ысулы бар. **Фонетик ысул** хәзерге татар телендә продуктив саналмый. Бу ысул б-н сүзләр ясалуның 4 төре билгеле: а) аваз төшеп калу (хәзер һәм әзер, гамәл һәм әмәл); б) авазлар чиратлашу (сан һәм сын, бөртек һәм бөрчек); в) нигезләр палатализациясе (нечкәрү) (аз — әз, акрын — әкрен); г) басым күчү (хәе́р һәм хә́ер, яңа́ һәм я́ңа). **Кушымчалау ысулы** бик продуктив санала. Бер үк кушымча исемгә дә, фигыльгә дә, сыйфатка да ялгана ала; мәс., -чы/-че кушымчасы тимерче, күнче сүзләрендә — исемгә, кадимче сүзендә — сыйфатка, меңче сүзендә — санга, күзәтүче сүзендә фигыльгә ялгана. **Сүзләр кушылуның** (ике яки сирәк кенә берничә нигезнең яки тамырның, бер сүз б-н кушылып, кушма сүз ясавы) татар телендә ике төре бар: а) компонентлары арасында тезүле бәйләнеш булган кушма сүзләр: бала-чага, савыт-саба, гореф-гадәт һ.б.; б) компонентлары арасында ияртүле бәйләнеш булган кушма сүзләр: терекөмеш, ташбака, елъязма һ.б. С.я.ның башка ысуллары: **сүзтезмәләрнең лексикалашуы**: сүзтезмәләрнең кушма сүзләргә күчүе: өч почмак — өчпочмак, күгәрчен күзе — күгәрчен күзе (чәчәк) һ.б.; **сүзтезмәләрнең, кушымча алып, кушма сүзләргә күчүе**: бишьел+лык, хәреф җыю+чы, сыер саву+чы һ.б.; **конверсия** — теге яки бу сүзнең бер сүз төркеменнән икенче сүз төркеменә күчүе: бай (сыйфат) — бай (исем), карт (сыйфат) — карт (исем), язучы (сыйфат фигыль) — язучы (исем); **лексик-семантик ысул** — бер сүз җирлегендә омонимнар барлыкка килү: йомгак — йомгак (нәрсәнең дә булса ахыры), ия (кеше) — ия (җөмләнең баш кисәге) һ.б.; **аббревиация** — сүзтезмәләрнең беренче иҗекләрен яки беренче хәрефләрен, яисә авазларын кушу юлы б-н сүзләр ясалу: ТИҮ — Татар иҗтимагый үзәге, ТРТ — Татарстан Республикасы телевидениесе.

2) Тел белеменең сүзләрнең ясалыш закончалыкларын һәм ысулларын өйрәнүче тармагы. И.И.Гиганов, И.Хәлфин, М.И.Иванов, К.Насыйри һ.б. тарафыннан төзелгән беренче татар теле грамматикаларында ук С.я.на караган мәсьәләләр өйрәнелә. 20 йөз башында чыккан грамматикаларда С.я. морфология тармагында карала. Җ.Вәлиди, М.Корбангалиев, Х.Бәдигый, Ш.Рамазанов та әлеге принципка таянып эш итәләр. Тел галимнәре В.Н.Хангилдин, Д.Г.Тумашева С.я.ның морфологик, синтаксик һәм морфологик-синтаксик ысуллары турында язалар. Югары уку йортлары өчен чыгарылган «Хәзерге татар әдәби теле» («Современный татарский литературный язык», М., 1969) дәреслегендә С.я.ның фонетик ысулы — лексикология тармагында, башкалары морфология тармагында өйрәнелә. «Татар грамматикасы»ның 1 нче томында (1998) С.я. татар тел белеменең мөстәкыйль бүлеге буларак карала.

*Әд.:* Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы. К., 2006; Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006; Ганиев Ф.А. Образование сложных слов в татарском языке. М., 1982; шул ук. Конверсия в татарском языке. К., 1985; шул ук. Современный татарский литературный язык: Суффиксальное и фонетическое словообразование. К., 2005.

*Ф.Ә.Ганиев.*

**СҮЗЛЕ́К**, 1) *лексика*, нинди дә булса социаль төркемнең, аерым язучының һ.б.ның теле яисә диалектының сүзлек составы. 2) Билгеле бер тәртиптә килүче (төрле төрдәге С.ләрдә төрле тәртиптә килүче) сүзләр (яисә морфемалар, сүзтезмәләр, идиомалар һ.б.) җыелмасын туплаган белешмәләр китабы, сүзләрнең мәгънәләрен аңлата, алар турында яисә аларның башка телгә тәрҗемәләре турында төрле мәгълүмат бирә (лингвистик С.ләр), төшенчәләргә аңлатма бирә, алар белдергән күренешләр, әйберләр, вакыйгалар, затлар турында мәгълүматлар китерә (энциклопедик С.ләр). С.ләр социаль функцияләр дә башкаралар: мәгълүмати (тупланган белемнәргә өстәмә мәгълүмат бирә), коммуникатив (укучыларга туган телнең яки чит телнең кирәкле сүзләрен җиткерә), норматив (сүзләрнең кулланылу мәгънәләрен һәм формаларын билгели). С.ләр төзү теориясе һәм практикасы б-н *лексикография* шөгыльләнә. Татар лексикографлары тарафыннан төрле төрдәге: тәрҗемә, ш.и. *икетелле сүзлекләр,* өчтелле сүзлекләр, *аңлатмалы сүзлекләр, фразеологик сүзлекләр,* диалектологик, этимологик, орфографик, терминологик, әдәби һәм әдәби терминнар, антонимнар, омонимнар, синонимнар һ.б. С.ләр эшләп чыгарыла. ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-ты тарафыннан әзерләнеп, татар һәм рус телләрендә басылып чыккан «Татар энциклопедия сүзлеге» (2002; «Татарский энциклопедический словарь», 1999) илебезнең тарихи-мәдәни һәм фәнни торышын билгеләүче зур вакыйга була (ТР Дәүләт бүләге, 2005). Сүзлекләр әзерләү һәм чыгару буенча төп фәнни эшчәнлек ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты тарафыннан алып барыла.

*Әд.:* Мөхәммәдиев М.Г. Татар теле лексикографиясенең һәм лексикологиясенең үсеше // Актуальные вопросы грамматики и стилистики татарского языка. К., 1981; Миңнуллин К., Вәлиуллин Р. Татар теле — сүзлекләрдә. К., 1998; Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006; Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка. К., 2001. Вып. 5.

**СҮЗТЕЗМӘ́**, ике яки берничә мөстәкыйль сүзнең төгәлләүле мөнәсәбәткә керүе нәтиҗәсендә ясалган иң кечкенә синтаксик берәмлек. Татар телендә гади С. (ике мөстәкыйль сүздән тора: хат язу, кызыл чәчәк) һәм катлаулы С. (гади сүзтезмәләргә таркалмый торган өч яки аннан күбрәк мөстәкыйль сүздән тора: керфеккә керфек какмау, биш кешелек эшләү) була. С.дә грамматик һәм семантик яктан өстенлек итүче сүз — ияртүче кисәк, ә грамматик яктан буйсынып килгән сүз иярүче кисәк дип атала. Ияртүче кисәкнең кайсы сүз төркеменнән булуына карап, С.ләр исем С. (укучының китабы), фигыль С. (җырны багышлау), сыйфат С. (баганадан биек), сан С. (уртадан бишенче), рәвеш С. (бөтенләй бушка), алмашлык С. (танышларымнан ул), хәбәрлек сүз С.гә (эш буенча кирәк) бүленә. Кисәкләре арасында лексик мәгънә сакланган ирекле (синтаксик) С. (ватанны ярату) һәм берәр кисәгенең яки барлык кисәкләренең дә лексик мәгънәләре йомшару яисә бөтенләй юкка чыгу нәтиҗәсендә ныгып калган ирексез (фразеологик) С. (кызган табага басыру — бик нык орышу) була.

*Әд.:* Зәкиев М.З. Татар грамматикасы. Синтаксис. М.–К., 1999. 3 т; шул ук. Татар синтаксисы. К., 2008; шул ук. Синтаксический строй татарского языка. К., 1963.


*М.З.Зәкиев.*

**СҮЛӘ́** (Өчиле) авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 23 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кече Мишә елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 53 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1930 елларга кадәрге рус чыганакларында По ключу Мендюш исемен йөртә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 506,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 36 ир-ат; 1859 да — 195, 1897 дә — 359, 1908 дә — 350, 1920 дә — 362, 1926 да — 379, 1938 дә — 397, 1949 да — 404, 1970 тә — 206, 1979 да — 486, 1989 да — 82, 2002 дә — 63 кеше.

**СҮНЧӘЛӘ́ЕВ** Кадыйрмөхәммәд (? — 1722 дән соң), дин эшлеклесе, тәрҗемәче, хаттат. Казан ахуны. 1722 елда император Пётр I күрсәтмәсе буенча Петербург ФА өчен Й.*Ижбулатов* б-н бергә Болгардагы 50 ләп кабер ташының язуын күчерә һәм тәрҗемә итә.

**СҮНЧӘЛӘ́Й** Сәгыйть Хәмидулла улы (2.8.1889, Саратов губ., Хвалынск өязе Иске Мастак а. — 27.10.1937, Зур Соловки утравы), язучы, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе. 1891 елда гаиләләре б-н Әстерхан шәһәренә күчеп китәләр, анда С. «Вәһабия» мәдрәсәсендә укый. 1907 дә Казан татар укытучылар мәктәбенә укырга керә. 1909–15 елларда абыйсы Ш.*Сүнчәләй* б-н Пермь губернасының Барда өязе Сараш авылы мәктәбендә укыталар. 1915 тә гаиләләре б-н Уфага күчеп киләләр; «Авыл халкы», «Көрәш» г-талары редакцияләрендә эшли. 1919 да, РСФСР Милләтләр эшләре халык комис-ты вәкиле буларак, Ак армия тарафыннан яуланган Кырымга яшерен эш алып бару максаты б-н җибәрелә. 1920 дә Төркиягә кача, 3 айдан Мәскәүгә кире кайта. 1921–22 дә яңадан Кырымда эшли. 1923–24 тә Башкортстан АССРның Мәгариф халык комис-тында коллегия әгъзасы һәм сәнгать бүлеге мөдире, соңыннан Уфада сәнгать музее директоры. 1926–27 дә Генераль консуллык составында Төркиядә эшли. 1927 дән Уфада, 1928 дән Казанда *Татар мәдәнияте йортында* эшли. 1929 да кулга алына, М.Х.Солтангалиев б-н бәйләнештә

торган өчен (к. «*Солтангалиевчелек*») үлемгә хөкем ителә. 1931 дә үлемне 10 еллык сөргенгә алыштыралар, 1937 дә С.не Соловки лагеренда атып үтерәләр. Үлеменнән соң аклана.



С.Х.Сүнчәләй.

Шигырьләренең күпчелеге иҗатының башлангыч чорында, авыл мәктәбендә эшләгән елларда языла. Сайлаган төп темалары — ватан, милләт, рев-ция, сәнгать, табигать, мәхәббәт. Күпчелек шигырь һәм истәлекләре Г.Тукайга багышлана. С.нең бу чор шигырьләре — яхшылык һәм яманлык, яшәү һәм үлем, мәхәббәт һәм нәфрәт турында уйланулар б-н тулган үзенчәлекле лирик көндәлек. Иҗатына хас сыйфат — автобиографиягә нигезләнү: аның лирик герое — авторның үз уй-хисләренең гәүдәләнеше. 1917 дән соң язылган шигырьләре («Ихтилал шигырьләре», Уфа, 1918; «Революцион шигырьләр», 1919; «Сәгыйть Сүнчәләй шигырьләре», 1929) күбесенчә декларатив, лирик герой образы әдәби яктан шартлы, чагылдырылган образдан автор читләшә кебек. Басылмый калган шигырьләрендә рев-циядән соңгы тормыш чынлыгының кайберләрен кабул итмәү, үзенең иҗтимагый эшчәнлегеннән канәгатьсезлек сизелә. «Мансур» (1916), «Сәнгатьчеләр» (1917; 1961 дә басыла) пьесалары, әдәбият, журналистика, мәдәният мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр авторы. Татар теленә русчадан В.А.Жуковский, И.А.Крылов, А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, И.С.Тургенев, Т.Г.Шевченко, А.А.Блок, К.Д.Бальмонт әсәрләрен, Дж.Байронның «Шильон тоткыны» поэмасын (1911), Һ.Һейненең «Әлмансур» (1913, 1919 да «Сәйяр» труппасы куя) пьесасын, И.Гриневскаяның «Баб» (1912–15, басылмаган) трагедиясен тәрҗемә итә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1961; Әсәрләр һәм хатлар. К., 2005.

*Әд.:* Р ә м и е в З. Вакыт җитәр, кояш чыгар // Казан утлары. 1989. № 8; М у с а б е к о в а Р.Р. Сагит Сунчелей: судьба и творчество. К., 2001.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**СҮНЧӘЛӘ́Й** Шәриф Хәмидулла улы (3.10.1885, Саратов губ., Хвалынск өязе Иске Мастак а. — 9.11.1959, Мәскәү), педагог, журналист, җәмәгать эшлеклесе. С.Х.*Сүнчәләйнең* абыйсы. 1903–07 елларда Казан татар укытучылар мәктәбендә укый. 1907–17 дә Сараш (Пермь губ.), Каргалы (Уфа губ.) авылларында укыта. 1917 дән Уфада. Г.Ибраһимов һәм Ф.Сәйфи-Казанлы б-н бергә «Ирек» г-тасын нәшер итүдә катнаша. 1917–18 дә «Авыл халкы» һәм «Безнең юл» г-талары мөхәрририятендә эшли. Уфа губерна Советының халык мәгарифе бүлеге мөдире. 1922 дән БАССРның Мәгариф халык комис-тында, Гыйльми Үзәк җитәкчесе; 1927 дән Халык мәгарифе ин-ты директоры. 1929–30 да халык мәгарифе ин-ты нигезендә оешкан Башкорт пед. ин-ты директоры. 1930 еллардан Мәскәүдә фәнни-пед. эштә.

*Р.Г.Хәйретдинов.*

**СҮРӘ́** (гарәп. سورة — саф, рәт), *Коръән* бүлеге. Коръәндә 3 тән алып 286 га кадәрге аятьне сыйдырган 114 С. бар. Һәрбер С.нең әһәмиятле сүзе, җөмләсе, аерым вакыйгалары, каһарманы, С.нең беренче сүзе б-н бәйле исеме була. *Мөхәммәд* пәйгамбәрнең дини эшчәнлеге чорларыннан чыгып, Мәккә чоры (610–622; 90 С.) һәм Мәдинә чоры (622–632; 24 С.) С.ләренә бүленә. Мәккә чоры С.ләренә төп эчтәлеге Аллаһның берлеге һәм кодрәтлелеге идеясе һәм тасвирлауларыннан торган рифмалы проза хас. Мәдинә чоры С.ләре фәкъһ кагыйдәләренә басым ясаган риторик проза, күп илаһлыкны катгый гаепләү, Мөхәммәд пәйгамбәрнең рухани һәм сәяси миссиясенең расланушы б-н аерылып тора. Мөселман йолалары уздыруда аерым С.ләрнең роле гаять зур, мәс., *Фатыйха* — Коръәндәге беренче С. (сүзгә сүз — «ачучы») барлык мөселман йолаларында; 36 нчы *Иа Син* С.се рухи һәм физик газап чиккәндә, ураза тотканда, искә алу-күмү йолаларын башкарганда укыла. Кайбер С.дәге аерым өзекләр бөти итеп файдаланыла, аларның аятьләре *шәмаилләргә* күчереп языла, хәзерге рәсми исламда бөтиләр кире кагыла. Ш.у.к. *Бөти*.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**СҮРӘКӘ́**, керәшен хатын-кызларының традицион баш киеме. 20×6 *см* зурлыктагы катыргыга яки каен тузына тегелгән тукыма кисәгеннән гыйбарәт. Бер ягыннан чигелгән, күбесенчә көмеш һәм алтынсыман җепләр б-н тулысынча уралып, баудан катлаулы бизәк өстәп тегелә. С. ике өлештән тора: С. үзе һәм колакчыннарның үзгә төре — чигәчә. Колакчыннар якынча 6x10 *см* зурлыктагы озынча эллипсның яртысы формасындагы 2 каен тузы яки кабык кисәгеннән гыйбарәт. Алар ике яктан да киндер тукыма б-н тышланган, бер ягына бер-берсенә тәңкәсыман кысрыклап көмеш тәңкәләр тегәләр. Төп буйның өске ягына 20x80 *см* зурлыктагы ситса яки чуар тукымадан зәңгәр яисә куе кызыл төстәге тукыма кисәге тегелә. Баш киеме баш түбәсен, җилкәне, муенны томалый һәм аркага төшеп тора. Тукыма очы чигелгән яки чуклы. С. иң кырыеннан өстән гадәттә кара төстәге шәл яулык чите б-н бераз бөкләнгән була, очлары бәйләнә яки җилкәдә тоташтырып куела. С. мәләнчек һәм тәңкәдән эшләнгән чигәчә б-н бергә киелгән. 20 йөздә С. милли киемнәрнең күп кенә башка элементлары б-н бергә көнкүрештән төшеп кала.

*Әд.:* Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; С у с л о в а С.В. Женские украшения Казанских татар середины XIX — начала XX вв.: Ист.-этногр. исслед. М., 1980; М у х а м е д о в а Р.Г. Народный костюм татар-кряшен. К., 2005.

*Р.Р.Батыршин.*

**СҮРҮЛӘРНЕ́Ң НӘСЫЗЫКЧА́ МЕХА́НИКАСЫ**, деформацияләнүчән каты җисем механикасының катлаулы системалар конструкциясендәге юка тышчалы элементлар деформациясен модельле күзаллаулар нигезендә өйрәнә торган бүлеге. С.н.м. теориясендә, деформация процессын сурәтли торган тигезләмәләр яки чикләү шартлары нәсызыкча булса, матем. модель дә нәсызыкча була. Нәсызыкчалык көчәнеш һәм деформацияләрнең пропорциональлеге турындагы Гук законы бозылган очракта: көчеш һәм деформация арасындагы бәйләлек нәсызыкчага әверелсә, ш.у. деформация процессында көч кую шартлары үзгәргәндә килеп чыга. Нәсызыкча матем. модульләрнең иң характерлы үзенчәлеге булып аларда суперпозиция принцибы бозылу тора. С.н.м. теориясе гамәли кулланылышы б-н әһәмиятле: төрле рәвешле юка тышчалы конструкцияләр (сүрү системалары) материалларының нәсызыкча деформациясен китереп чыгара торган шартларда эшлиләр. С.н.м. иң кечкенә авырлыктагы машиналар, механизмнар, очкыч аппаратлар, корылмалар тудырырга ярдәм итә. Казанда С.н.м. мәктәбе (Х.М.*Мөштәри* нигез сала) 1930 елларда формалаша һәм Казан ун-тында, РФА КГҮнең Механика һәм машиналар төзү ин-тында, Казан техник ун-тында үсеш ала. Төп юнәлешләре: сыгылмалы юка сүрүләрнең нәсызыкча геом. теориясе, сүрүләр теориясе мәсьәләләренең санлы чишелешләре, өч һәм күпкатлы пластиналар һәм сүрүләр (К.З.*Галимов*, А.В.*Саченков*, М.С.*Корнишин*, М.Ә.*Илһамов*, В.Н.*Паймушин*, Н.С.*Ганиев*, И.Г.*Терегулов* һ.б.). С.н.м. буенча теоретик һәм эксперименталь тикшеренү нәтиҗәләре халык хуҗалыгының төрле тармакларында: машиналар, приборлар төзүдә, төзелештә (аерым алганда, Казан циркы төзелешендә) кулланыла.

*Әд.:* М у ш т а р и Х.М., Г а л и м о в К.З. Нелинейная теория упругих пластин и оболочек. К., 1957.

*Ю.Г.Коноплёв.*

**СҮСӘ́Н** (Apera spica venti), кыяклылар семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлек, чүп үлән. Татарстан терр-ясенең барлык төбәкләрендә — яткын җирләр, болыннар, көтүлекләр, сөзәклекләрдә таралган. Чук тамырлы. Сабаклары туры, шома, 25–100 *см* һәм аннан да биегрәк, еш кына көчле куаклык барлыкка китерә. Яфраклары сызыклы, киңлеге 5 *мм* га кадәр, яссы. Июль–августта чәчәк ата һәм җимеш бирә. Чәчәк төркеме — таралучан яисә җыелма себеркәч, озынлыгы 25–30 *см*, очлы кытыршы ботакчыклар б-н. Башаклары вак, бер чәчәкле, кылчыклы, озынлыгы 2,5–3 *мм* га кадәр, аксыл шәмәхә һәм яшел төстә. Җимеше — ялангач тар очлы бөртекчә, озынлыгы 1,5 *мм* га кадәр. Орлыктан үрчи. Бер үсемлек 16 меңгә кадәр орлык бирә, алар туфракта 4 елга кадәр саклана. Җәй көне яисә шул ук елның көзендә тишелеп чыга. С. туфракны начарайта һәм киптерә, уңыш җыюны авырлаштыра. Терлек азыгы буларак әһәмиятсез үсемлек. Хайваннар яшь үсентеләрен генә ашый.

**СҮСӘНӘ́К** (Crypsis), кыяклылар семьялыгыннан үләнчел үсемлекләр ыругы. 15 кә якын төре билгеле, Евразия һәм Африканың уртача һәм субтропик поясларында таралган. ТРда 2 төре бар: камышсыман С. (C. schoenoides) һәм төлке койрыклы С. (C. alopecuroides). Ике төре дә — берьеллык, 5–30 *см* биеклектә. Идел һәм Кама елгасының комсу ачык елга утырмаларында очрый. Яссы яки буйга төрелгән яфрак пластинкалары җиргә җәелгән. Тамыр системасы — чук. Чәчәк төркеме — башаксыман себеркәч. Башаклары бер чәчәкле, ян-яктан кысылган. Җиме-

ше — бөртекчә. Май–июньдә чәчәк аталар. Орлыктан үрчиләр. Камышсыман С.нең өске ике яфрагы нык кабарынкы җиңсәле булуы б-н аерылып тора. Терлек азыгы (казлар, үрдәкләр яратып ашый). Ике төре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**СХО́ДНЕВО-ЧЕРТАНЛА́** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 28 *км* төньяк-көнбатыштарак, Куак елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 57 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 19 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Чертанла исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында миссионерлык мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1318 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Каратаевка волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 256, 1889 да — 336, 1910 да — 364, 1920 дә — 494, 1926 да — 479, 1938 дә — 460, 1949 да — 455, 1958 дә — 474, 1970 тә — 439, 1979 да — 231, 1989 да — 136, 2002 дә — 84 кеше.

**СЫБЫЗГЫ́**, татар халкының иркен тибрәлүчән телле музыка уен коралы. Бер башы ябык, икенче башы кыек яисә көпшәгә перпендикуляр киселгән, 100–150 *мм* озынлыкта, 4–6 *мм* диаметр калынлыктагы камыш торба. Ачык башы б-н торбаның ябык өлешенә караган кисек теле өзгеч ролен үти. Ачык башыннан



Сыбызгы.

аваз чыгару өчен, С.ны иреннәр б-н кысып, торба куышлыгына өрәләр. Өзгеч «тәрәзә»се аша чыккан һава, телне бераз күтәреп, аны тибрәндерә. Тавышы ачы, безелдәвек. С.ның динамик мөмкинлеге — mf-ff. С. бер, ике, өч, яисә дүрт тишекле итеп эшләнә. Уен коралының динамик мөмкинлеге һәм тавыш югарылыгы теленең калынлыгы, киңлеге, озынлыгыннан һәм торба куышлыгына кергән һава агымыннан тора. Осталар телне аеруча җентекләп ясыйлар, һәр киселгән миллиметрдан соң тиешле югарылыкта һәм ешлыкта барлыкка килгән тавыш чыгару мөмкинлеге тикшерелә. Телләрне кискәндә чыга торган авазларның интервал нисбәте музыкант-осталар тарафыннан билгеләнә. Еш кына телләрне көйләү авазларның терция нисбәте б-н гамәлгә ашырыла. С. секунд көйләнеше б-н ясала. Элек бу уен коралы киң таралган булган, аны көтүчеләр кулланган. Көтүчеләр сигналлы һәм импровизацияле көйләр башкарганнар. С.ларның аерым төрләре — үрдәк сыбызгысы, торна сыбызгысы һ.б. аучылар тарафыннан киекләрне чакырып китерү өчен эшләнә һәм кулланыла.

*Р.Халитов.*

**СЫЕРКОЙРЫ́К** (Verbascum), сыраҗчалар семьялыгыннан үләннәр һәм ярымкуаклар ыругы. 350 гә якын төре билгеле, Евразия, Төньяк Африкада һәм, үтеп кергән үсемлек буларак, Төньяк Америкада таралган. ТР терр-ясендә 8 төре бар. Себеркәчле С. (V. lychnitis), кара серкәчле С. (V. nigrum), гади С. яки аюколак (V. thapsus) барлык районнарда киң таралган. Биберштейн С.ы (V. biebersteinii), калкулык С.ы (V. collinum), Маршалл С.ы (V. marschallianum) — респ-ка флорасы өчен сирәк төрләр. Комлы туфракта, урман аланнарында, болыннарда, елга ярлары буенда үсәләр. 2 *м* биеклектәге ике- һәм күпьеллык үсемлекләр. Сабагы берле, туры. Яфраклары бөтен, чиратлашкан, озынча, тамыр яныңдагылары — таралгыда. Чәчәкләре сары, кызыл, ак, катлаулы чук чәчәк төркемендә. Җимеше — күпсанлы көрән вак орлыклы түгәрәк-йомыркасыман тартмачык. Июнь–августта чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Чәчәкләрендә сапонин, флавоноид, шикәр, кумарин, лайлалы матдәләр, каротин бар. Халык медицинасында чәчәк таҗчыклары төнәтмәсе какырык куптару чарасы буларак кулланыла. Кипкән яфракларын хайван яраларына сибәләр. Күп кенә төрләре баллы. Кара серкәчле С. һәм себеркәчле С. — чүп үләннәр.

**СЫЕРЧЫКЛА́Р**, сыерчык кошлар (Sturnidae), чыпчыксыманнар отрядындагы кошлар семьялыгы. 110 га якын төре билгеле, башлыча, Көнчыгыш ярымшарның тропик һәм субтропикларында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар. Гади сыерчык (Sturnus vulgaris) барлык районнарда да очрый. Март ахыры – апрель башында очып килә. Торак пунктларда, ара-тирә урман буйларында һәм елга тугайларында яши. Уртача зурлыктагы кош. Каурый капламы тыгыз, каты, металлсыман төсмерле кара, каурый очлары аксыл чуар. Томшыгы нәзек, аз гына аска бөгелгән. Койрыгы кыска. Аяклары көчле. Агач куышларына, әзер ояларга парлашып яки колония булып оялыйлар. 5–7 зәңгәр йомырка сала. Җәен күчмә яшәү рәвеше алып бара, бөҗәкләр ш.и. май һәм июнь коңгызлары, кара коңгызлар, филчекләр, күбәләкләр һәм аларның гусеницалары, ш.у. җимешләр һәм орлыклар б-н туклана. Сентябрь–октябрьдә кышлар өчен очып китә. Ал сыерчык (Pastor roseus) — очып керүче сирәк төр. Башы бүрекчәле, канат һәм койрыгы кара, калган каурыйлары ал төстә. Нигездә, саранчалар б-н туклана.



Гади сыерчык.

**СЫЗА́** (балка), тау битләрендә кар һәм яңгыр сулары б-н юылу (эрозия) нәтиҗәсендә барлыкка килүче үзән. Ерымнан кәсләнгән, еш кына куаклык һәм урманнар б-н капланган сөзәгрәк битләүләре б-н аерыла. Сызаларның озынлыгы — йөз метрдан берничә километрга, тирәнлеге — берничә дистә метрларга кадәр. Үләннәр б-н каплану нәтиҗәсендә үсүдән тукталган ерымнарда тар төпле һәм чагыштырмача текә битле яшь С.лар барлыкка килә. Киң һәм җиңелчә батынкы яки яссы төпле борынгы С.лар бозлык алды чоры климаты һәм мәңгелек туңлык шартларында солифлюкация процесслары барышында формалашкан, өлешчә комсыл балчык һәм вакланган таш юылудан, ш.у. грунт агудан ясалган. Урман кискәндә һәм җир сөргәндә вакытлыча аккан сулар С. төбендә чокырлар һәм икенчел ерымнар хасил итә. Җир асты сулы горизонтлар ачылганда, С.лар елга үзәннәренә әйләнә. ТР терр-ясе, аеруча аның калкулыклары гомуми озынлыгы 39,1 мең *км* һәм уртача тыгызлыгы 0,58 $км/км^2$ булган тыгыз С. челтәре б-н ергаланган, бу исә ерым челтәренең озынлыгын һәм тыгызлыгын 2,7 һәм елга челтәрен 1,8 тапкыр узып китә. Идел, Кама, Вятка, Чишмә, Зәй, Зөя һ.б. елга үзәннәренең биек уңъяк текә битләүләрен С.ның аеруча тыгыз һәм тирән челтәре кискәли. С.лар буалар кору, көтүлекләр, бакчалар үстерү өчен файдаланыла.

*А.П.Дедков.*

**СЫЗГА́НОВ** Александр Николаевич (17.8.1896, Сембер губ., Ардатов өязе Иске Жабино а. — 8.10.1980, Алма-Ата), хирург, мед. фән. д-ры (1936), Казакъстан ССР ФА академигы (1954; 1946 дан мөхбир әгъзасы), Казакъстан ССРның атказ. фән эшлеклесе (1947). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1922), шунда ук оператив хирургия һәм топографик анатомия кафедрасында эшли. 1926–34 елларда Казан мед. ин-тының госпиталь хирургиясе клиникасында. ТАССРда Кан салу ин-тын (1929) оештыручыларның берсе. 1934–63 тә Алма-Ата мед. ин-тында, оператив хирургия һәм топографик анатомия кафедрасын оештыручы һәм мөдире, проф. (1934). Бер үк вакытта, 1945–75 тә, Клиник һәм экспериментал хирургия фәнни-тикшеренү ин-ты директоры (аның катнашында төзелә). Институт каршында онкология үзәге, йөрәк-кан тамырлары хирургиясе бүлеге ачыла. Казакъстанда хирургия үсеше тарихы музее оештырыла. Респ-ка кан салу станциясен (1934) оештыручы һәм җитәкчесе; Алма-Ата зоб диспансерын (1930) нигезләүче, ш.у. Алма-Ата өлкәсендә эпидемик зоб авыруы чыганакларын ачыклау һәм авыруның таралышын өйрәнү өчен беренче экспедицияләрне (1935) оештыручы. 1941–45 тә Алма-Ата эвакогоспитальләре консультанты. Хезмәт-

ләре коллатераль лимфа әйләнешенә, эпидемик зобны өйрәнүгә, хәрәкәтләрне тиз төзәтү, ашказаны-эчәк трактындагы яман шешләрне дәвалау ысулларына карый, канцерогенез теориясен эшләп тәкъдим итә. Казакъстан ССР ЮС депутаты (1955–80). Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О лимфатической системе почек и почечных оболочек человека. А.-А., 1940; О некоторых условиях развития злокачественных опухолей. А.-А., 1970; О способах применения салициловой кислоты и йода при лечении гнойных хирургических заболеваний. А.-А., 1977 (автордаш).

*Әд.:* У р а з а н о в И.У. Памяти академика Александра Николаевича Сызганова // Вестн. хирургии. 1981. Т. 126, № 5.

**СЫЗГЫРА́К ЧЫПЧЫКЛА́Р** (Bombycilla), сызгырак кошлар семьялыгыннан кошлар ыругы. 3 төре билгеле, Евразиядә, Төньяк Америкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади сызгырак чыпчык (B. garrulus) бар. Күчеп йөрүче, ара-тирә кышлаучы төр. Бик күптөрле агач-куак биотопларында, парк, бакчаларда һәм торак кварталларда яши. Гәүдәсенең озынлыгы 15–18 *см*,



Гади сызгырак чыпчык.

авырлыгы якынча 60 *г*. Каурый капламы йомшак, алсу-соры төстә, канатлары кара, сары һәм ак буйлары бар, койрыгы аркылы сары каймалы. Башы кызгылт-коңгырт каурыйлы зур купшы бүрекчәле. Койрыгы кыска. Томшыгы җиңелчә бөгелгән, киң төпле, очында кечкенә ыргаклы. Чутырдавы еш-еш, көйле. С.ч. тиз, җиңел очалар. Ояларын агачта коралар. Кара-коңгырт тимгелле 3–7 зәңгәрсу-соры йомырка салалар. Җиләкләр (кара җиләк, кук җиләк), җимешләр (миләш, алма, гөлҗимеш һ.б.), бөҗәкләр б-н тукланалар. С.ч. күп кенә үсемлекләрнең таралуына булышлык итәләр.

**СЫЙФА́Т**, предметның билгесен (сыйфатын, үзлеген) белдерә торган сүз төркеме. Җөмләдә күбесенчә аергыч, сирәк кенә хәбәр булып килә. Татар телендә С.ларның түбәндәге лексик-семантик төркемчәләре билгеле: 1) төсне белдерүче С.лар (яшел, сары); 2) тәм ягыннан билгене белдерүче С.лар (тәмле, татлы); 3) исне белдерүче С.лар (хуш исле); 4) предметның зурлыгын, күләмен белдерүче С.лар (озын, кыска, зур, тулы); 5) предметның формасын белдерүче С.лар (яссы, түгәрәк); 6) предметның физик торышын белдерүче С.лар (каты, йомшак); 7) вакытны белдерүче С.лар (язгы, кичке); 8) кешенең тышкы сыйфатларын белдерүче С.лар (ямьсез, матур, аксак); 9) холык үзенчәлекләрен белдерүче С.лар (юаш, усал); 10) акыл үзенчәлекләрен белдерүче С.лар (акыллы, надан) һ.б. Татар телендә С.лар грамматик яктан билгеләнмәгән (аларны башка сүз төркемнәреннән аера торган форма күрсәткечләре юк). Лексик-грамматик яктан С.лар 2 төркемчәгә бүленә: асыл С.лар һәм нисби С.лар. Асыл С.лар предметның (яки затның) саф билгесен белдерәләр, ягъни аны нинди дә булса билгесе буенча ачыклыйлар: аяз (күк), яхшы (кеше), зур (шәһәр) һ.б.; нисби С.лар бер предметның икенче предметка (яки затка), күренешкә яисә төшенчәгә булган мөнәсәбәтен билге итеп күрсәтәләр: кышкы (юл), музыкаль (әсәр), көндәлек эш һ.б. Асыл С.ларның 4 дәрәҗәсе аерып өйрәнелә. Төп (гади) дәрәҗә предмет яки затның гадәти билгесен белдерә: ак (күлмәк), кечкенә (авыл), зур (кыз). Чагыштыру дәрәҗәсе бер предметтагы (заттагы) билгенең, башка предметка (затка) караганда, чагыштырмача артыграк булуын белдерә: аграк, кечкенәрәк. Артыклык дәрәҗәсе билгенең иң югары дәрәҗәсен, чиген белдерә. Ул бер предметтагы (заттагы) билгенең шундый ук икенче бер предметтагы (заттагы) билгедән бик күпкә артык булуын чагыштыру аша һәм гомумән белдерергә мөмкин: ап-ак, бик кечкенә, иң яхшы. Кимлек дәрәҗәсе предметтагы (заттагы) билгенең гадәттәгедән кимрәк булуын белдерә. Бу дәрәҗә формалары даими рәвештә ясалмый. Алар, нигездә, төс һәм тәм ягыннан билгене белдерүче сыйфатларга хас: аксыл, әчкелтем, төчкелтем.

*Әд.:* Татар грамматикасы. Морфология. М.-К., 2002. 2 т.; Х и с а м о в а Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006; С а ф и у л л и н а Ф.С., З ә к и е в М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006; И с х а к о в Ф.Г. Имя прилагательное // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. М., 1956. Ч. 2.

**СЫЙФА́Т ФИГЫ́ЛЬ**, үзендә *фигыль* һәм *сыйфат* сүз төркемнәре үзенчәлекләрен берләштергән затланышсыз фигыль формасы. Татар телендә С.ф. фигыльнең түбәндәге семантик һәм морфологик билгеләренә ия: 1) семантик яктан С.ф.ләрдә башка фигыль формаларындагы кебек эш-хәл, процесс мәгънәсе белдерелә: **килгән** кеше, **исә торган** җил; 2) морфологик яктан С.ф.ләрдә фигыльгә хас төп грамматик категорияләр саклана: *юнәлеш* категориясе кушымчаларын ала (**сөйләүче**, **сөйләтүче** кеше), барлык-юклык (**укыган**, **укымаган** китап), заман (**укучы, укый торган** бала, **әйткән** сүз, **очар** кош) б-н төрләнә; эшнең үтәлү дәрәҗәсе (эшнең күп тапкырлар кабатлануы) синтетик һәм аналитик юл б-н белдерелә ала (**баргалаган** җир, **укый башлаган** китап). Синтаксик яктан С.ф.ләр килешләр б-н башкарылалар (**суга бара торган** сукмак), иярчен җөмләдә хәбәр булып киләләр. С.ф.нең сыйфатка хас семантик үзенчәлеге булып аның предметның эш-хәл буенча билгесен белдерүе тора (**агылучы** болытлар). Аергыч функциясендә (атрибутив мәгънәдә) килгәндә С.ф. килеш, тартым, сан б-н төрләнми (морфологик билге): **ял итүче** кешеләргә, **ял итүче** кешеләрне. Исемләшкәндә (субстантивация), С.ф. сыйфат кебек үк килеш, тартым, сан б-н төрләнә. Синтаксис яктан С.ф. җөмләдә күбрәк аергыч функциясен башкара. Еш кына С.ф. исем фигыль функциясендә килә. Хәзерге татар телендә С.ф. түбәндәге заман формаларына ия: 1) үткән заман С.ф. Ул -ган/-гән (-кан/-кән) кушымчасы б-н ясала: **килгән** кеше, **пешкән** җиләк; 2) хәзерге заман С.ф. Аның гади (-учы/-үче кушымчалы: **килүче** кеше) һәм тезмә (-а торган/ -ә торган (-ый торган/-и торган) формалы: **килә торган** кеше, **яши торган** йорт) формасы бар; 3) киләчәк заман С.ф. Аның өч төре билгеле: -ыр/-ер/-р (-ар/-әр) кушымчалы С.ф.: **әйтер** сүз; -ачак/-әчәк (-ячак/-ячәк) кушымчалы С.ф.: **булачак** җыелыш; -асы/-әсе (-ыйсы/-исе) кушымчалы С.ф.: **киләсе** кеше, **сөйлисе** сүз.

*Әд.:* Татар грамматикасы. Морфология. М.–К., 2002. 2 т.; Х и с а м о в а Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006; С а ф и у л л и н а Ф.С., З ә к и е в М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006.

**СЫКТЫВКА́Р** шәһәре, РФдә, *Коми Республикасы* башкаласы, Мәскәүдән 1515 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 1586 елдан Усть-Сысольск торулыгы буларак билгеле; хәзерге исемен 1930 дан йөртә. Халкы — 257921 кеше (2013). Татарлар саны: 1989 да — 1641, 2002 дә — 1480, 2010 да — 1377 кеше. С.да татар җәмгыяте Бөек Ватан сугышыннан соң оеша башлый. Беренче булып Ульянов өлкәсеннән һәм ТАССРның көньяк-көнбатыш р-ннарыннан (Чүпрәле һ.б.) социаль юнәлешле объектлар (мәктәпләр, ашханәләр һ.б.) төзелешенә контракт б-н эшләргә килүчеләр күчenә. 1960 елларда Сыктывкар урман сәнәгате комплексы үсү б-н, татарлар саны арта. Хәзерге вакытта С.да «Дуслык» Татар мөселман мәдәният үзәге (1993), Татар һәм башкорт милли-мәдәни автономиясе (1993), «Татарстан» милли-мәдәни автономиясе (1996, рәисе — Л.Х.Даутова), аның каршында «Яшьлек» клубы, «Мөслимә» хатын-кызлар җәмгыяте, Ислам мәдәният үзәге, «Нур» мәхәлләсе» мөселман дини оешмасы (2000, җитәкчесе — Ф.Х.Ибраһимов) эшли. Ел саен *Сабан туе, Ураза бәйрәме, Корбан бәйрәме*, поэзия көннәре; Г.*Тукай*, М.*Җәлил* һәм аның көрәштәшләренә багышлап, балалар өчен әдәби уен-тамашалар уздырыла. 1552 дә Казанны саклаучыларга багышлап, Хәтер көне, Татарстан Респ-касы оештырылган көн билгеләп үтелә. Шәһәрдә Казанның 1000 еллыгына, Г.Исхакыйның тууына 130 ел тулуга багышланган бәйрәм чаралары үткәрелә. Генерал-майор В.Т.*Насыйров*, филос. фән. д-ры С.М.Әюпов, җырчы Ә.*Коротаеваның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге С. шәһәре б-н бәйле.

**СЫНАМЫ́Ш**, фольклор прозасы жанры. Дәвамлы күзәтүләргә, практик тәҗрибәгә яисә төрле ышануларга нигезләнгән алдан әйтү, фаразлау, киңәшне үз эченә ала. Татар сынамышларын туплау, өйрәнү һәм классификацияләү б-н Н.Исәнбәт, Х.Мәхмүтов, Г.Ахунҗанов һ.б. шөгыльләнә. Күк җисемнәрен, табигать күренешләрен, флора, фауна һ.б.ны күзәтүләргә нигезләнгән һава торышын һәм булачак уңышны фаразлау, а.х. эшләре буен-


ча киңәшләр булган сынамышлар аеруча күп өйрәнелгән: «Тау башларында кар күп булса, җиләк уңар», «Мәче тырнашса, җил чыгар», «Озынборыннар яздан ук биектә очсалар, солы уңар».

*Әд.:* Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре: 3 томда. К., 1959–67; Сынамышлар // Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр. К., 1987; Татар халык иҗаты: Хрестоматия. К., 2005.

*Ф.И.Урманчеев.*

**СЫНЛЫ́ СӘНГА́ТЬ**, нәкышь, графика, скульптура әсәрләре кергән сәнгать үрнәкләре бүлеге. С.с. реаль тормыштагы күреп аңлый торган сыйфатларны (күләм, төс, форма, фәза) күрсәтмә образларда тергезү. Татар С.с.енең формалашуы мәҗүси борынгы төрки сәнгать культурасы элементлары һәм ислам сәнгать хасиятләре кергән күпкомпонентлы үзенчәлекләргә, башлыча, гамәли-бизәк төшерү иҗаты формаларына бәйле (к. *Болгар бизәлеш сәнгате, Алтын Урда сәнгате, Ислам сәнгате, Казан ханлыгы сәнгате*). Бер үк вакытта, 16 йөзнең 2 нче яртысыннан, Татарстан терр-ясендә борынгы рус сәнгатенең аерым төрләре — икона ясау, фреска үсеш ала; 17 йөз ахырыннан сәнгатьтә мәдәниятнең дөньявилыгына нигезләнгән яңа принциплар ныгый. С.с. үсеше төрле стилистик системалар — барокко, классицизм, романтизм, салон академизмы, модерн, символизм, футуризм һ.б. йогынтысында бара. С.с. төрләренең үзенчәлекләре тирәнәя, жанрлар системасы формалаша. 18–19 йөзләрдә С.с.не өйрәнү урта һәм югары уку йортлары программасына кертелә (Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе, ун-т, руханилар академиясе, реаль уч-ще һ.б.). Казанда Ф.П.*Травкинның* шәхси рәсем мәктәбе эшли. С.с. күбесенчә портретлар (К.В.Барду, И.И.Журавлёв, Н.И.Зеблов, Л.Д. һәм Л.Л.Крюковлар, Р.А.Ступин, Ф.И.Чекиев һ.б.), табигать күренешләре (Э.Турнерелли, В.С.Турин, А.Н.Ракович һ.б.), тарихи-дини нәкышь (И.И.Нечаев, Ф.Д.Колосов, В.С.Турин, П.Д.Пономарёв һ.б.), ш.у. китап графикасы һәм журнал иллюстрациясе (А.В.Котельников, Н.Н.Кафтанников, П.Т.Табуре, Ф.Ткачук, Л.Кальмер һ.б.) жанрларында үсә. 19 йөз дәвамында Казан төбәгендә күренекле рус рәссамнары К.Ф.*Гун*, А.П.*Боголюбов*, Г.Г. һәм Н.Г.*Чернецовлар*, В.Г.*Худяков*, И.И.*Шишкин* һ.б.ның төрле елларда эшләп алулары мәгълүм. Театр-бизәлеш нәкыше М.И.Живокини, Г.Я.Паулино иҗатында үсеш ала. 1895 елда *Казан сынлы сәнгать мәктәбе* ачылу С.с. осталары — нәкышьчеләр, графиклар, скульпторлар әзерләүгә ныклы нигез сала, нәтиҗәдә, аларның күпчелеге Татарстан, Чуашстан, Башкортстан, Удмуртия, Урал һәм Ерак Көнчыгышта С.с.нең формалашуы һәм үсүендә әйдәүче роль уйныйлар, халыкара танылу алалар (Н.И.*Фешин*, Д.Д.*Бурлюк*, А.М.*Родченко*, К.Ф.*Зале*, К.К.*Чеботарёв* һ.б.). Н.И.Фешинның иҗаты һәм пед. эшчәнлеге С.с. үсешенә хәлиткеч йогынты ясый. 19–20 йөзләр чигендәге С.с. төрле стилистик алымнарның көчлелеге һәм катлаулылыгы б-н аерылып тора (импрессионизм, модерн, футуризм). Театр-бизәлеш сәнгатенең күтәрелеш вакыты П.П.Беньков иҗаты б-н бәйле. С.с.нең беренче татар проф. осталары арасында Г.Гомәров, С.Яхшыбаев, Х.*Акчурина*, Ш.Таһиров, К.*Дәүләткилдиев*, М.*Байкиев*, Г.Камал бар. 20 йөзнең 1 нче чирегендә С.с.үсеше «*Подсолнечник*», «*Всадник*», «*ТатЛЕФ*», *Сулф*, «Октябрь» сәнгать берләшмәләренең, 1936 дан ТАССРның *Рәссамнар берлегенең* иҗат эшчәнлекләре б-н бәйле. Казан дәүләт архит-ра-сәнгать остаханәләре С.с. осталарын әзерләү үзәгенә әйләнә (к. *Казан сынлы сәнгать училищесе*). Җәмгыятьнең социаль-сәяси ихтыяҗлары С.с.тәге өндәмә-гаммәви төрләрнең бик көчле үсешенә сәбәпче була: Пролеткульт һәм ТатЛЕФ идеологиясе сәяси плакат, китап һәм газета-журнал сәнгате стиленә сизелерлек йогынты ясый (к. *Монументаль сәнгать, Дизайн*). С.с. үсешенә нәкышьчеләр Н.И.Фешин, П.П.Беньков, К.К.Чеботарёв, П.П.*Радимов*, Г.А. һәм Г.Г.*Медведевлар*, Б.И.*Урманче*, Н.М.*Сапожникова* һ.б., графиклар Н.С.*Шикалов*, И.Н.*Плещинский*, В.Э.*Вильковиская*, Н.М.*Сокольский*, Ф.С.*Быков*, Х.А.*Алмаев*, Ф.Ш.*Таһиров*, А.Н.*Коробкова*, Д.Н.*Красильников*, Б.Г.Йосыпов, Д.Г.*Булат* һ.б., скульпторлар В.С.Богатырёв, В.С.Козлов зур өлеш кертә. 1930–50 елларда С.с. үсеше коммунистик идеология, соц. реализм, партиялелек һәм халыкчанлык принциплары кысаларында бара. Эчтәлекнең әһәмиятенә, социаль мәгънәле күренешләрне сайлап алуга юл тоткан, ачыктан-ачык өндәүле юнәлеше һәм социаль әһәмияте булган станлы нәкышь үсешенә өстенлекле әһәмият бирелә (Д.П.Архипов, Д.Г.Булат, П.И.Байбарышев, М.М.Васильева, И.И.Казаков, И.И.*Князьков*, В.Л.Лаптев, А.К.Лукоянов, В.А.Родионов, Н.М.Сокольский, Ш.Н.*Мөхәммәтҗанов*, Н.К.*Вәлиуллин* һ.б.). Театр-бизәлеш нәкыше өлкәсендә В.С.*Никитин*, П.Т.*Сперанский*, М.Г.*Сутюшев*, ш.у. Казанда вакытлыча эшләгән Россия рәссамнары Н.А.Андреев, Д.Л.Боровский, Н.Н.Золотарёв, П.А.Злочевский, Б.Г.Кноблок, А.А.Осмёркин, Т.И.Сельвинская һ.б. хезмәт күрсәтә. Графикада күбрәк плакат, китап һәм газета-журнал илл. үсеш ала (Г.Я.Мусин, М.З.Кәримов, Б.М.Әлминов, Ш.Н.Мөхәммәтҗанов, А.А.Хохряков, Н.М.Сокольский һ.б.). Бөек Ватан сугышы елларында Х.Г.*Якупов*, М.Г.*Усманов*, А.М.*Родионов*, Д.Г.Булат, Г.Д.Мелентьев, В.А.Попов, М.И.Семёнов, А.Г.Хуторов һ.б. фронт рәсемнәре циклын иҗат итәләр. Сәяси плакат жанрында Р.Ф.Сәйфуллин, Б.М.*Әлминов*, И.Е.*Бобровицкий*, Э.Б.*Гельмс*, Н.М.Сокольский, А.А.Прытков һ.б. хезмәт куя. Скульптура акрынлык б-н үсә (С.С.*Ахун*, В.В.Ламмерт, К.С.Счастнев, И.А.Новосёлов, Н.П.Тузов). С.с. үсеше 1960–80 елларда бөтен совет сәнгатенә хас булган «кырыс стиль» кысаларында эчтәлек һәм форманы кискен яңарту процесслары б-н характерлана: сәнгатьтән әдәбилек һәм күрсәтмәлелекне куып чыгару, публицистик башлангычны көчәйтү, дөнья сәнгате мәдәни традицияләренең тагын да киңрәк мохитен үзләштерү башлана. Алга таба монументаль сәнгать һәм *бизәлеш сәнгате* үсеш ала. Татарстанның С.с. е зона, бөтенроссия, бөтенсоюз күргәзмәләрендә үзен торган саен күбрәк таныта. С.с. осталарын әзерләүдә Казан сынлы сәнгать уч-щесе б-н беррәттән СССРның халык рәссамы Х.Г.Якупов җитәкчелегендәге *Россия Сәнгать Академиясенең иҗат остаханәсе* дә (1977 дән) әһәмиятле роль уйный. Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзаларының саны арта, илнең сәнгать уку йортларында югары белем алган һәм респ-ка сәнгатен яңа стилистик үзенчәлекләр б-н баеткан С.с. осталары саны да үскәннән-үсә (А.Ә.*Абызгилдин*, З.Ф.*Гыймаев*, И.К.*Зарипов*, Е.В.*Зуев*, В.А.*Килдебәков*, В.Н.*Скобеев*, Ш.М.*Шәйдуллин*, В.К.*Фёдоров*, И.Я.*Язынин*, С.М.*Кульбака*, И.К.*Колмогорцева*, В.В.*Карамышев*, Э.Я.*Зарипов*, Э.Г.*Ситдыйков*, В.А.*Попов*, Л.А.Потягунин, Л.М.Кальюранд, Т.А.*Зуева*, Б.И.*Майоров* һ.б.). Өлкән буын рәссамнары: Х.Г.Якупов, Л.Г.*Фәттахов*, М.Г.*Усманов*, С.О.*Лывин*, А.Л.*Прокопьев*, А.М.Родионов, К.Е.*Максимов*, Б.И.*Урманче*, Г.А.*Рахманкулова*, В.И.*Кудelькин*, Н.Д.*Кузнецов*, Г.Д.*Мелентьев* һ.б. С.с. үсешенә лаеклы өлеш кертәләр. Графикада эстамп сәнгатенең линогравюра, офорт, литография төрләре яңарыш кичерә (Ю.Б.Лысогорский, Т.А.Зуева, М.К.*Мавровская*, Л.М.Кальюранд, Э.Г.*Ситдыйков*, В.А.Попов, И.К.*Әхмәдиев*, Э.Я.Зарипов, Л.А.Потягунин, Е.В.Киселёва, И.Л.Язынин һ.б.). КамАЗ объектлары төзелешендә, нефть районнарында, авылларда эшләү өчен Татарстан Рәссамнар берлеге каршында С.с. осталарының иҗат төркемнәре оештырылу С.с. әсәрләрендә респ-ка тормышын тагын да киңрәк күзалларга мөмкинлек бирә. Татар мәдәниятенең олуг шәхесләренә (Г.Тукай, М.Җәлил һ.б.) багышланган юбилей чаралары, дәүләти һәм рев-цион бәйрәмнәр тарихи жанрның алга таба үсешенә этәргеч көч булалар. Татарстан китап нәшриятының бизәлеш редакциясе китап графикасы тарихында әйдәп баручы рольне уйный. Сатирик графика «Чаян» ж-лы рәссамнары иҗатында үстерелә. Каты материаллардан — агач, мәрмәр, бронза, шамоттан эшләнгән скульптура сәнгате дә кызу темплар б-н үсә (әйдәп баручы осталар арасында — Б.И.Урманче, В.М.*Маликов*, В.И.Рогожин, А.Х.*Әбдрәшитов*, Н.И.*Гаделев*, Ә.К.Бәширов, Г.А.Зяблицев). Мемориаль скульптура жанры әсәрләре респ-ка районнарында киң таралыш таба. Казанда М.Җәлилгә (В.Е.Цигаль, 1967), «Совет власте өчен көрәштә һәлак булганнарга» (В.М.Маликов, 1967), А.М.Бутлерова (Ю.Г.Орехов, 1978) һ.б. һәйкәлләр куела. С.с., респ-ка сәнгать культурасының тагын да зуррак тәэсирле көченә әверелеп, Казан чикләреннән тыш та кызу темплар б-н үсә: Әлмәт (Р.Агафонов, В.Бушурова, Н.Горланов, Р.Гомәров, А.Максютин, Г.*Стефановский* һ.б.), Бөгелмә (Ф.Корнилов, Р.*Круглякова*, Б.Мәрданов, Р.Мәхмүтов, И.Насретдинов, Н.Осокин, Д.Рәхмәтуллин һ.б.), Алабуга (М.Кузнецов, З.Миңнәхмәтов, Р.Сәлахов һ.б.), Яшел Үзән (Р.*Галиуллин*, А.Крылов, Х.Сибгатуллин һ.б.), Лениногорск (Я.Зиннәтуллин, О.*Кульпин*, Д.Садретдинов, М.*Хәйретдинов*, А.Юдин һ.б.), Чаллы (Н.*Бикташев*, Э.Бусова, А.*Вашуров*, Х.Гыймазетдинов, Е.Грабенко, А.Дербилов, Г.Иванов, В.Никольский, И.*Ханов*, А.Халдеев, М.Шәйдуллин һ.б.),


1


2



3


4


5


6




8



9



10


11


12


13


14


15


16


**Сынлы сәнгать мәкаләсенә.** 1. Л.Д. К р ю к о в. «К.Ф. Фукс портреты». Акварель. 1828. ТР Милли музее; 2. А.Н. Р а к о в и ч. «Казандагы Петропавел соборы». 1840 еллар уртасы. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 3. В.С. Т у р и н. «Казан кирмәне күренеше». Картондагы кәгазь, офорт, майлы буяу. 1820 еллар. ТР Милли музее; 4. В.Г. Х у д я к о в. «Казан татары кызы». 1869. Дәүләт Рус музее. С.-Петербург; 5. Г.А. М е д в е д е в. «Борынгы җыр». 1900 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 6. Л.О. С и к л е р. «Казан антиквары Якуп Ишмиев портреты». 19 йөз ахыры – 20 йөз башы. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 7. Шәмаил. Типографик басма. 1894. ТР Милли музее; 8. Н.И. Ф е ш и н. «Бәләкәй Катя портреты». 1912. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 9. А.Ф. М а н т е л ь. «Советча декор үрнәге». Картон, гуашь, акварель. 1920 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 10. Н.С. Ш и к а л о в. «Кышкы шәһәр». Төсле линогравюра. 1920 еллар башы. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 11. А.Н. К о р о б к о в а. «Азат хатын» журналы тышлыгы эскизы. Кәгазь, гуашь. 1927. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 12. П.А. Р а д и м о в. «Татар ишегалды». 1927. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 13. К.К. Ч е б о т а р ё в. «А.Г. Платунова портреты». 1933. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 14. Ш.Н. М ө х ә м м ә т җ а н о в. «Ашчы белән ишегалды себерүче мәхәббәте». 1930 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 15. Б.И. У р м а н ч е. «Автопортрет». 1930 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 16. К.Е. М а к с и м о в. «Нарат урманы. Камага юл». 1953. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.



1



2



3



4



5



6



7




8



9



10



11




12



13



14



15


**Сынлы сәнгать мәкаләсенә.** 1. Л.А. Ф ә т т а х о в. «Сабан туе». 1957. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. Н.Д. К у з н е ц о в. «Казан – биш диңгез порты». 1959–60. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 3. Л.А. П о т я г у н и н. «Сөембикә манарасы». Төсле линогравюра. 1959. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 4. Х.Г. Я к у п о в. «Атаклы терлекче М. Галимуллина портреты». 1960–61. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 5. И.В. Р ә ф ы й к о в. «Кунакка». 1964. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музе; 6. Ә.И. Т у м а ш е в . Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясенә декорация эскизы. Кәгазь, гуашь. 1957–64. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 7. П.Т. С п е р а н с к и й. Р.Г. Гобәйдуллинның «Кисекбаш» балетына декорация эскизы. Картон, темпера. 1959–61. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 8. Э.Б. Г е л ь м с . Д. Вәлиевнең «Дәвам» («Тормыш бүләк итәм») спектакленә декорация эскизы. Кәгазь, гуашь, аппликация. 1977. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 9. С.М. Б у б е н н о в, В.К. Ф ё д о р о в . «Совет Татарстаны». Казан тимер юл вокзалы бинасы диварындагы композиция. Сграффито, мозаика. 1967; 10. С.М. Б у б е н н о в, П.И. М а к а р о в. Казандагы «Татарстан» кунакханәсе фойесындагы мозаика. Идел буе Болгар дәүләте халыклары тормышы темаларына. Төсле смальта, мозаика. 1970; 11. И.М. Х ә л и у л л о в. «Җир хуҗалары». 1969. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 12. Е.В. З у е в. «Өчпочмак һәм пәрәмәч». 1978. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 13. Т.Г. Х а җ и ә х м ә т о в. Кол Галинең «Йосыф вә Зөләйха» поэмасына иллюстрация. Ксилография, акварель. 1971; 14. М.Г. У с м а н о в «Нефть-бензинга бай Түбән Кама». 1978. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 15. В.Н.С к о б е е в. «Кама өстендә акчарлаклар». 1974. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.



1




2



3



4



5



6




7



8



9




10



11



12



13

**Сынлы сәнгать мәкаләсенә.** 1. Б.И. У р м а н ч е. «Печән базары». 1975; 2. А.Л. П р о к о п ь е в. «Идел. Яңгырдан соң». 1963. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 3. Б.И. У р м а н ч е. «Сөембикә». Агач. 1978; 4. В.И. К у д е л ь к и н. «Иделлеләр». 1981–83; 5. В.К. Ф ё д о р о в. Төзүчеләр мәдәният сарае фасады витражы. Төсле пыяла. Кургаш. 1981; 6. А.Ә. А б ы з г и л д и н. «Казанда яз». «Сабан туе» сериясеннән. 1985; 7. В.И. Р о г о ж и н. «Дирижёр Натан Рахлин». Гипс. 1984–85; 8. В.Я. А к и м о в. «Күккә ашу». 1990; 9. И.М. Х а н о в. «Прометей». 1998; 10. Р.А. Г ы й л ә җ е в. «Суык көн». 1993; 11. З.М. М и ң н ә х м ә т о в. «Казан». 1998; 12. В.А. П о п о в. «Бисмиллаһ – изге Кәгъбә. Казанның 1000 еллыгына багышлана». Оргалит, темпера. 2001; 13. И.К. З а р и п о в. «Уракчы кыз». 2001.

Түбән Кама (Г.Капитонов, Ә.Фәтхетдинов, Р.Мәрданшин, Р.Шиһабетдинов һ.б.). Үзәктән читтә эшләүче рәссамнар иҗатында төп урынны яшь шәһәрләр һәм район үзәкләрендә ихтыяҗ булган монументаль-бизәлеш сәнгате алып тора (җәмәгать урыннарын, уку, мәдәни-агарту учреждениеләрен бизәү). 1980–90 еллардагы яңарыш чоры үзенчәлекләрен яктырткан һәм мәдәни ихтыяҗларны кабат күздән кичергән мәдәни хәрәкәт процесслары С.с.тә дә эз калдыра. Ул соц.-идеологик заказдан читләшә. Узган чор сәнгать әсәрләренең публицистиклыгы метафоралылыкка омтылган шәхси кызыксынуга, милли менталитетка, хисси-интуитив башлангычлар әзләүгә урын бирә. Бер үк вакытта, реализмның киң спектрлы стилистик төрләре б-н (А.Ә.Абызгилдин, Р.Килдебәков, Ш.Шәйдуллин, И.Зарипов, В.Акимов, Ю.Свинин, О.Кульпин, Ә.Ильясова, Б.Гыйльванов, Р.Заһидуллин, М.Хаҗиев, В.Анютин һ.б.) С.с.тә поставангард юнәлешләр төрлелеге дә күзәтелә (В.Аршинов, Н.Әлмиев, Е.Голубцов, В.Нестеренко, А.Бусыгин, И.Ханов, И.Гыймранов, А.Артамонов һ.б.). Яңа, үзенчәлекле иҗат берләшмәләре һәм төркемнәре барлыкка килә: «17 нче төркем» (Р.Абаев, О.Бойко, Е.Голубцов, А.Леухин, В.Нестеренко, Ә.Якупов һ.б.), «Дастан» (Ә.Сәйфетдинов, М.Якушев, И.Сафин, Р.Заһидуллин, А.Галимов һ.б.), «Чыңгызхан» (Н.Лотфуллин, В.Ханнанов, Р.Әхмәтвәлиев һ.б.), «Ансваки» (В.Анютин, Ю.Свинин, В.Акимов), «Татарстан рәссамнары берләшмәсе» (Г.Вәлиева-Сөләйманова, Р.Вахитов, Х.Нәфыйков, И.Зарипов, Л.Гыйльметдинов һ.б.). Хаттатчылык һәм шәмаил сәнгате аякка баса (Н.Нәккаш, Ф.Гыйрфанов, Р.Шәмсутов, В.Попов һ.б.).

Татарстан рәссамнарының хезмәтләре зона, бөтенроссия һәм халыкара күргәзмәләрдә катнаша (к. *Сынлы сәнгать күргәзмәләре*), Россия (Третьяков галереясы, Рус музее һ.б.) һәм чит ил музейлары тупланмалары составына керә. С.с. әсәрләренең зур җыентыклары ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, Әлмәт, Чаллы шәһәрләрендәге картиналар галереяларында, Казандагы Б.Урманче музее һәм И.Зарипов галерея-студиясендә, шәхси тупланмаларда («Туран» фонды) һ.б. да саклана.

*Әд.:* Д у л ь с к и й П.М. Памятники Казанской старины. К., 1916; ш у л у к. Искусство в Татреспублике за годы революции. К., 1929; Ч е р к а с о в а Н.В. Изобразительное искусство Советского Татарстана. К., 1957; ш у л у к. Искусство Татарии // История искусства народов СССР. М., 1972. Т. 6; Е л ь к о в и ч Л.Я. Художники Татарии. Л., 1965; Искусство стран и народов мира: Краткая худож. энцикл. М., 1971. Т. 3; В а л е е в а Д.К. Искусство волжских булгар (X — нач. XIII вв.). К., 1983; ш у л у к. Искусство Татарстана (20 век). К., 1999; ш у л у к. Искусство волжских булгар периода Золотой Орды (XIII–XV вв.). К., 2003; Ф а й н б е р г А.Б. Художники Татарии. К., 1983; В а л е е в Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Ч е р в о н н а я С.М. Искусство Советской Татарии. М., 1978; ш у л у к. Художники Советской Татарии. К., 1984; ш у л у к. Искусство Татарии. История изобразительного искусства и архитектуры с древнейших времён до 1917 г. М., 1987; Н о в и ц к и й А.И. Баки Урманче. К., 1994; В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920 — нач. 1990-х гг.). К., 1995; Государственный музей изобразительных искусств Республики Татарстан: Альбом. К., 1997; С у л т а н о в а Р.Р. Искусство новых городов Татарстана. 1960–90-е гг. К., 2001; Н и г м а т у л л и н а Ю.Г. «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. К., 2002.

*Е.П.Ключевская.*

**СЫНЛЫ́ СӘНГА́ТЬ КҮРГӘЗМӘЛӘРЕ́**, сынлы сәнгать әсәрләренең, вакытлыча (даими музей экспозициясеннән аермалы буларак) халыкка күрсәтелүе. Россиядә беренче әзлекле С.с.к.н С.-Петербург СА оештыра. С.с.к.н 19 йөздән ш.и. Казанда да уку йортлары, музейлар, җәмәгать һәм иҗат берләшмәләре, аерым кешеләр уздыра башлый.

С.с.к.н оештыру принциплары һәм әсәрләрне күргәзмәләрдә күрсәтелүе картиналарны гади күрсәтмәләрдән башлап махсус җиһазлардан, дизайн һәм архит-ра чараларыннан файдаланып, җентекләп төзелгән программа буенча урнаштыруга кадәр юл уза. С.с.к.н турыдан-туры оештыру эшләрен вазифаларына күргәзмә концепциясен әзерләү, тематика-экспозиция планын төзү, әсәрләрне комплектлаштыру, экспозиция төзелеше, маркетинг һ.б. кергән жюри, күргәзмә ком-ты (сайланган яки билгеләнгән составта) башкара. С.с.к. үткәрелү әзлеклелеге (әзлекле — ел саен, көзге, язгы һ.б.; әзлексез — юбилейга, истәлекле вакыйгага багышлана); катнашучыларның составы (халыкара, төбәк, шәһәр; төркемле, аерым зат); сәнгать төрләре һәм жанрлары (нәкышь, скульптура, графика, гамәли-бизәлеш һәм театр-бизәлеш; пейзаж, портрет, натюрморт һ.б.), ш.у. сәнгатьтәге темалары һәм юнәлешләре буенча төркемнәргә бүленәләр. 19 йөз уртасыннан башлап, Казан зур күргәзмәләр эшчәнлеге үзәге булып таныла. Биредә 3 нче (1874), 14 нче (1886), 17 нче (1889) Күчмә сәнгать күргәзмәләре ширкәте; Сәнгать академиясе (1889); «Сәнгать дөньясы» (1910), 11 нче Рус рәссамнары берлеге (1914) күргәзмәләре уздырыла. Хәйриячелек максатында шәхси тупланмалардагы әсәрләр күргәзмәләре үткәрелә (1879, 1891, 1916). Вак һөнәр сәнгате һәм сәнгать бүлекләре губерна фәнни-сәнәгый һәм а.х. күргәзмәләренең аерылгысыз өлешенә әвереләләр (1845, 1847, 1852, 1886, 1890, 1909). Аларда Идел буе татарлары һәм башка халыкларның күргәзмәләргә үзенчәлекле төсмер бирүче нәкышь, скульптура, милли гамәли бизәлеш сәнгате һәм сәнгать һөнәрләре әсәрләре күрсәтелә. 1890 елгы күргәзмә коллекцияләре шәһәр фәнни-сәнәгать музее (хәзер ТР Милли музее) оештыруга нигез була. Халыкара вак сәнәгать һәм һөнәри белем күргәзмәсе экспонатлары нигезендә (1909) *Казан губерна земствосының вак сәнәгать һәм һөнәри белем бирү Үзәк музее* ачыла. *Казан сынлы сәнгать мәктәбе* Петербург, Мәскәү, Смоленск, Сембер һ.б. шәһәрләр осталары катнашында ел саен (1896–1916) «Җирле һәм чит шәһәрләр рәссамнарының вакытлы күргәзмәләре»н үткәрә. Казан рәссамнары һәм Күчмә сәнгать күргәзмәләре ширкәте әгъзалары, Рус рәссамнары берлеге, Рәссамнарның яңа җәмгыяте, «Салон» һ.б. иҗат берләшмәләре катнашында мәктәп тарафыннан оештырылган иң зур С.с.к.се — «Хәзерге заман рус сәнгате» (1909). Күргәзмәләрне ш.у. *Казан нәфис сәнгать сөючеләр җәмгыяте* дә уздыра. Н.Е.Лунд (1901), поляк рәссамы Батовский, Татмейер, Коссак (1907), Е.Д.Вучичевич (1908) һ.б. әсәрләреннән торган күргәзмәләрнең асылы коммерциягә корылган була.



Казандагы Беренче республика гамәли-бизәлеш сәнгате күргәзмәсе экспозициясе. 1983. ТАССР Рәссамнар берлегенең Күргәзмәләр залы.

Уку йортлары тематик күргәзмәләр оештыралар: 1 нче һөнәр уч-щесендә — борынгы офорт (1912, Казан), Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә — 1812 елгы «Ватан сугышы истәлегенә» (1912) һ.б. уза. С.с.к.н үткәрү өчен Дворяннар җыены, шәһәр думасы, юнкерлар уч-щесе, гимназияләр, сынлы сәнгать мәктәбе залларыннан урын бирелә. Экспозицияләр гомуми композиция идеясен алга куймый. Күргәзмәләр картиналар сату б-н чиратлашып бара, һәм, кагыйдә буларак, каталоглар бастырыла. С.с.к. сәнгать мәдәнияте формалашуга, тәнкыйть үсеше, шәхси тупланмалар барлыкка килүгә юл ача. Күргәзмәләр эшчәнлеге 1920 еллар башыннан күзгә күренеп үсә. ТАССРны игълан итү елы зур сәяси мәгънә салынган С.с.к. б-н билгеләп үтелә («Беренче дәүләт сәнгать һәм фән күргәзмәсе», «Шәрекъ халыклары мәдәнияте күргәзмәсе»). 1920 еллар башында барлыкка килгән төрле иҗат берләшмәләре — *«Подсолнечник», «Всадник», «ТатЛеф», ТатАХРР* — күргәзмә эшчәнлекләренең махсус программаларына ия була. 1920 елларда даими рәвештә Казан сәнгать ин-тының конкурс диплом эшләре күргәзмәләре оештырыла.

1920–30 елларда ТАССР Үзәк музее зур күргәзмә эшчәнлеге алып бара. П.М.*Дульский* җитәкчелегендәге сәнгать бүлеге совет сынлы сәнгатенең әйдәп баручы осталары (К.Ф.Богаевский, Г.С.Верейский, А.Д.Гончаров, Н.Н.Куприянов, А.И.Кравченко, Е.С.Кругликова, Д.И.Митрохин, Г.К.Пискарёв, А.А.Пластов, В.А.Фаворский, П.А.Шиллинговский, К.Ф.Юон), ш.и. Казан рәссамнарының (В.Э.Вильковиская, И.И.Плещинский, Н.С.Сокольский һәм В.А.Родионов һ.б.) шәхси С.с.к.н уздыра. Каталоглар төзүгә әйдәп баручы сәнгать белгечләре —

Э.Ф.Голлербах, Ф.Ф.Нотгафт, Н.Г.Машковцев, П.Д.Эттингер һ.б. җәлеп ителә. Басмалар күчемсез фәнни мәгънә саклый һәм раритет характерда була (исемле һәм номерлы нөсхәләр, график илл. автор тактасыннан алып басылалар). Музей тарафыннан ш.у. «ТАССР Үзәк музеена Мәскәүдәге дәүләт музей фонды бүлеп биргән картиналар күргәзмәсе» (1927), «ТАССР Үзәк музееның сәнгать бүлегенә яңа кергән картиналар күргәзмәсе» (1929), «Капитал илләрендә революцион графика» (1934) һ.б. күргәзмәләр уздырыла.

1935 тә ТР Рәссамнар берлеге оештырылганнан бирле С.с.к. үткәрү иҗатны бәяләүдә төп критерий, берлеккә әгъза итеп кабул итүгә, мактаулы исемнәр, бүләкләр бирүгә нигез булып тора. С.с.к. аша картиналарны дәүләт тарафыннан сатып алу оештырыла. Шуның нәтиҗәсендә алар, заман сәнгате коллекцияләрен формалаштыруда төп чыганак буларак, музей тупланмаларына тапшырылалар. 1936 да «Татарстан рәссамнарының беренче күчмә күргәзмәсе» Зеленодольск шәһәрендә уздырыла. 1940–50 елларда респ-каның Апас, Актаныш, Алабуга, Баулы, Бөгелмә, Буа, Зеленодольск, Минзәлә, Нурлат, Тәтеш, Чистай һ.б. район үзәкләрендә даими рәвештә күчмә С.с.к. үткәрелә башлый.

Дәүләт бәйрәмнәре һәм юбилей даталарына багышланган респ-ка С.с.к. үткәрүгә аеруча зур әһәмият бирелә (Окт. рев-циясе, Җиңү көне, ТАССР, СССР төзелү, ВЛКСМ һәм КПСС съездлары һ.б., 1990 елларда — Респ-ка көне).

Мәдәният эшлеклеләренә (М.Җәлил (1966, 1976, 1991), Г.Тукай (1976) һ.б.) багышланган С.с.к., ш.у. Б.Урманче исем. Респ-ка бүләген бирүгә тәкъдим ителгән әсәрләр күргәзмәләре оештыру (1999 дан — ел саен) сынлы сәнгатьтә милли теманың үсешенә булышлык итә.

1960 еллар уртасыннан тематик С.с.к. репертуары шактый киңәя («Казан рәссамнары туган шәһәрләре турында», 1966; «Сынлы сәнгатьтә Казан Кремле», 1970; «Сынлы сәнгатьтә — Болгар», 1970; «Казан сувенирлары», 1972, 1974; «Ватан ядкәрләре», 1972; «КамАЗга багышлана», 1973; «Нефтьчеләргә — Татарстан рәссамнары», 1977, 1981; «Рәссамнар — авылга», 1983 һ.б.). С.с.к. катнашучыларның составы буенча да формалаша: фронтовик рәссамнар (1947), сәнгать уч-щеләре һәм балалар сәнгать мәктәпләре педагоглары (1965, 1972, 1977, 1982 һ.б.), карикатурачылар (1960, 1968, 1981, 1983 һ.б.), хатын-кыз рәссамнар (1966, 1972, 1973 һ.б.), яшь рәссамнар (1967, 1969, 1971, 1972, 1973, 1974, 1976, 1977, 1978, 1982 һ.б.) күргәзмәләре. С.с.к. сәнгатьнең аерым төрләре һәм жанрлары буенча да даими рәвештә үткәрелеп тора: агитплакат (1945, 1963, 1967, 1977), графика һәм эстамп (1952, 1963, 1967, 1970, 1983, 1999), пейзаж (1966, 1970), скульптура (1986), театр-бизәлеш сәнгате (1974, 1982) һ.б. Үткәрү урыннары — мәдәният йортлары, Офицерлар йорты, Казан музейлары, ш.у. ТР Рәссамнар берлегенең Күргәзмәләр залы. С.с.к. Казаннан башка респ-каның район үзәкләрендә: Әлмәт, Бөгелмә, Алабуга, Лениногорский, Чаллы, Чистайда җирле рәссамнар катнашында да үткәрелеп килә.



ТР рәссамнарының көзге күргәзмәсе экспозициясе күренеше. 2000.
ТР Рәссамнар берлегенең Күргәзмәләр залы.



ТР Рәссамнар берлегенең Күргәзмәләр залы. Казан. Архитекторлар Г.А.Бакулин, Р.Х.Галиев, В.П.Мулюкин, инж. Г.Н.Дружкова. 1979.

Татарстан мәдәнияте һәм сәнгате көннәренә багышлап оештырылган С.с.к. Мәскәү (1957, 1980–81), Йошкар-Ола (1961), Алма-Ата (1962), Ульяновта (1967) уздырыла. Татарстан рәссамнары күргәзмәләре Ташкент (1965), Уфа (1976), Баку (1979), Нөкестә (1980) һәм илебезнең башка шәһәрләрендә күрсәтелә.

Татарстан рәссамнары даими рәвештә бөтенсоюз, бөтенроссия, зона С.с.к.ндә (к. *Зур Идел*), 1931 дән — халыкара һәм совет сәнгатенең чит илләрдәге күргәзмәләрендә (Австрия, Болгария, Германия, Греция, Италия, Һиндстан, Кытай, Ливан, Польша, АКШ, Франция, Финляндия, Чехословакия, Япония һ.б. илләрдә) катнашып килә.

С.с.к. *Татарстан Республикасының Дәүләт сынлы сәнгать музее, Татарстан Республикасының Милли музее, «Казан» милли мәдәният үзәге, Әлмәт картиналар галереясы, Чаллы картиналар галереясы* һ.б. тарафыннан оештырыла. Музейларда үз тупланмаларыннан, ш.у. вакытлыча алмашу буенча башка музейлардан, аерым рәссамнардан, коллекционерлардан, җәмәгать оешмаларыннан алып уздырылган С.с.к. сәнгать тарихын өйрәнүдә, коллекцияләрне танытуда, агымдагы сәнгать процессын күзаллауда зур роль уйныйлар. Берничә музей катнашында «Татарстан музейлары хәзинәләре» (1998, Мәскәү, Тарих музее), «Борынгы Казан» (1999, «Казан» милли мәдәният үзәге) кебек зур күргәзмәләр оештырыла.

1990 еллардан башлап, С.с.к. ш.у. җәмәгать оешмалары, шәхси галереялар, «Ислам һәм хәзерге заман татар сәнгате» (1995, «Туран» фонды); «Төрки дөнья» (1996 дан — ел саен, «Алтын Урда» ассоциациясе); «Эбиволь», «Камил», «Ак бүре» галереялары һ.б. көче б-н үткәрелә.

*Әд.:* Д у л ь с к и й П.М. Выставки Центрального музея ТАССР. К., 1927; М о г и л ь н и к о в а Г.А. Художественные выставки в Казани во второй половине XIX в. К., 1958; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; К л ю ч е в с к а я Е.П. Казанские вернисажи сто лет назад // Татарстан. 1997. № 5; В а л е е в а Д.К. Искусство Татарстана. XX век. К., 1999; Союз художников Республики Татарстан между X и XI съездами. 1996–1999. К., 2000.

*Е.П.Ключевская.*

**СЫНЛЫ́ СӘНГАТЬТӘ́ ТАРИХИ́ ЖАНР**, сәнгатьтә халыклар тарихындагы социаль әһәмиятле күренешләргә багышланган төп жанрларның берсе. Тарихи вакыйгаларны сурәтләү озак вакытлар мифлар, фольклор һәм дини темалар б-н бәйләп карала. Әлеге жанрның үсеше һәм үзенчәлеге тулаем тарихи, социаль-сәяси фикер үсешенә сәбәпче була. 17–18 йөзләрдә академизм һәм классицизм сәнгатендә С.с.т.ж. өстенлекле сыйфатта раслана, 19 йөздә аллегорик һәм дини жанрлар б-н бөтенләй арасын өзә. Ул еш кына башка жанрлар — *көнкүрешне сурәтләү жанрлары* (тарихи-көнкүреш композицияләр), *портретлар* (тарихи-портрет композицияләре, тарихи эшлеклеләрнең портретлары), *пейзажлар* (тарихи пейзажлар) б-н үрелеп бара. С.с.т.ж. сугыш вакыйгаларының мәгънәсен һәм әһәмиятен ача торган сугыш күренешләрен тасвирлаучы жанр б-н аеруча тыгыз бәйләнгән. Станлы (*нәкышь, скульптура, графика*) һәм монументаль сәнгатьтә (дивар бизәкләре, рельефлар, һәйкәлләр), ш.у. вак пластикада (медальләр) гәүдәләнә. 16 йөзнең 2 нче яртысыннан башлап, борынгы рус сәнгате традицияләре кысаларында Татарстан терр-ясендәге Зөя, Казан, Алабуга, Бөгелмә һ.б. шәһәрләрдәге, күп кенә авыллардагы, монастырьлардагы храмнарның тарихи-дини бизәлеш цикллары төзелә. Сюжетларының тулылыгы, бирелешләренең үзенчәлекләре һәм саклану дәрәҗәләре буенча борынгы рус сәнгате тарихында Зөя шәһәренең Успение соборындагы дөнья яратылышы һәм җәннәттәге беренче кешеләрнең тормышыннан алып Гайса һәм Мәрьям Ана яшәгән чорга кадәрге Библия сюжетларын, ш.у. патша Иван Грозный һәм митрополит Макарий портретларын эченә алган 16 йөзнең 2 нче яртысы — 17 йөз башы фреска бизәкләренең тиңдәшсез циклы аерым урын алып тора. Тарихи, ш.и. Казан тарихы б-н бәйле сюжетлар икона язуга («Сугышчан чиркәү») һәм китап миниатюрасына («Бизәкле елъязмалар җыелмасы») үтеп кергән. 18 йөздән башлап тарихи-дини нәкышь ешрак акад. сәнгать стилендә иҗат ителә, бу исә осталарның икона язу һәм нәкышь цехларына бүленеп эшләүләренә китерә. 18 йөз ахырында — 19 йөз башында тарихи-дини нәкышь жанрында эшләүче осталар арасында Н.И.Зеблов, А.Т.Бомьин, Д.Колосов, П.Д.Мелентьев, А.И.Нечаев, В.С.Турин, Л.Д.Крюков (Казан), Алексей, Агафон һәм Александр Ла-

пицкийлар (Бөгелмә), П.И. һәм В.И.Первуниннар, К.Ф.Гун, И.А.Осокин, бертуган Верещагиннар (Алабуга) һ.б. бар. С.с.т.ж.ның чын мәгънәсендәге үсешен, башлыча, төрле халыкларның тарихы һәм мәдәниятенә һәрьяклап арта барган игътибар, археол. һәм этнография фәннәрендәге уңышлар билгеләде. Бу, үз чиратында, С.с.т.ж. сәнгать әсәрләрендә табигыйлеккә, детальләрнең тарихи төгәллегенә таләпчәнлекне арттыра. Танылган рус рәссамнары Г.И.Угрюмов (1764–1823), В.Г.Худяков (1825–71), К.Б.Вениг (1830–1908), Н.К.Рерих (1874–1947) һ.б.ның Казан тарихының төрле күренешләренә багышланган картиналары әлеге таләпләргә җавап бирә. 19 йөздә Казанда мемориаль характердагы һәйкәлләр (*Рус гаскәриләре һәйкәл-төрбәсе*), ш.у. Г.Р.Державин (скульп. С.И.Гальберг), император Александр II (скульп. В.О.Шервуд) монументлары, Н.И.Лобачевский бюсты (скульп. М.Диллон) куела. 1812 елгы Ватан сугышының 100 еллыгына һәм Романовлар йортының 300 еллыгына Казанда М.И.Кутузовка һәм Барклай де Толлига вакытлы һәйкәлләр, М.А.Густов, К.Ф.*Зале* катнашында иҗат ителеп, Россиягә багышланган символик монументлар салына. 19–20 йөзләр чиге сәнгатендә, гүзәллек һәм шигърият чыганагы буларак, борынгы истәлекләр б-н кызыксыну уяна, бу Г.А.*Медведев*, В.С.Щербаковның аерым әсәрләрендә чагылыш таба. 1920 еллардан С.с.т.ж.да романтика һәм символика б-н сугарылган тарихи-революцион тема әйдәп баручы урынны ала. 1920 еллар рәссамнары иҗатында универсальлек өстенлек итә, С.с.т.ж.га мөрәҗәгать итү иҗади махсуслашу характерында булмый. К.К.Чеботарёв, П.М.Байбарышев, Д.Г.*Булат*, С.Козлов һ.б.ның 1905, 1917 еллардагы рев-цияләр һәм Гражданнар сугышы темаларына багышланган нәкышь һәм график әсәрләренә драматик вакыйгаларның кискенлеге, персонажларның ачыклыгы, композицияләрнең динамиклыгы хас. К.К.Чеботарёвның Окт. рев-циясе темасына монументаль бизәлеш эскизлары (Дәүләт Третьяков галереясында) совет сәнгатендә беренчеләрдән булып нәкышь сәнгатенең әлеге төрендә чорның сәнгать символы мәгънәсенә ия булалар. Тарихи портрет жанрына респ-када беренчеләрдән булып рус һәм чит ил композиторлары портретлары сериясен тудырган Н.И.*Фешин* мөрәҗәгать итә (Ф.Лист, А.Рубинштейн, Л. ван Бетховен һ.б.). Рев-ция көрәшчеләре һәйкәлләренең, ш.и. вакытлыларының да проектларын ленинчыл монументаль пропаганда нигезендә Ф.П.*Гаврилов* һәм В.С.*Богатырёв* иҗат итә. Станлы скульптурада «ленинчыл» һәм революцион темалар Г.А.*Козлов* иҗатында гәүдәләнеш таба. 1930 еллар сәнгатендә С.с.т.ж. тагын да ачыграк төс ала. Тарихи нәкышьтә сыйнфый көрәш, феодалларга каршы сугышлар һәм аларның юлбашчылары темасы өстенлек итә, элек сәнгатьтә чагылыш тапмаган сюжетлар эшләнә (борынгы төркиләр, болгарлар, урта гасырлардагы Казан, Казан төбәгендә Е.И.Пугачёв, С.Т.Разин җитәкчелегендәге крәстияннәр кузгалышы һ.б.).

Тарихи нәкышьнең төп герое — халык. Вакыйгаларны сурәтләгәндә тарихи нәкышькә дөрес, төгәл, ышанычлы мәгълүматларга таяну хас. Респ-ка нәкышендә тарихи жанрны тудыруга И.И.*Князьков* лаеклы өлеш кертә. 19 йөзнең 2 нче яртысындагы рус тарихи жанры традицияләренә таянып, рәссам картинаны гаммәви, күп фигуралы күренешләр б-н тулыландыра, бай хәрәкәтле композиция кора барып, аерым төсле тапларның хисле чагылышына басым ясап, сюжетларның драматургиясен һәм иконографиясен, персонажларның типажын һәм холкын җентекләп өйрәнә. Экспонатларны комлекслы күрсәтү принцибын экспозицион-күргәзмә музей эшендә экспонатларның күргәзмә күренешләрен ачу, тулыландыру һәм конкретлаштыру бурычы куелган нәкышьле панно һәм картиналар бәйләнешендә куллану С.с.т.ж. үсешенә этәргеч бирә. Шуңа охшаш панно-картиналар циклын ТАССР Үзәк музее (хәзерге ТР Милли музее) заказы буенча элгәреге урта гасырлар Идел-Кама төбәге темаларына В.Л.*Лаптев* төзи. Тарихи портрет һәм тарихи мифлар темасы С.С.*Ахунның* монументаль һәм станлы скульптураларында гәүдәләнеш таба. С.с.т.ж.га сынчы К.С.Счастнев та (1900–57) мөрәҗәгать итә. 1940–50 еллар сәнгатендә С.с.т.ж. тематикасы шактый киңәя, аңа тартылган рәссамнар саны арта. Россия тарихында Казанның әһәмиятен ачкан (аерым алганда, мәдәният тарихында — А.М.*Родионов*, Л.Г.*Фәттахов*, А.П.*Бурлай*, Р.В.*Нурмөхәммәтов*, Г.В.*Житков* һ.б.ның картиналары), А.С.Пушкин, М.Горький, Ф.И.Шаляпин, В.В.Маяковскийның Казанга килүенә багышланган сюжетлар эшләнә. Революцион хәрәкәт тарихы темаларына язылган картиналарда да төбәкне өйрәнү карашы сизелә. Л.А.Шалина, В.К.*Тимофеев*, Н.М.*Сокольский*, И.Н.Овчинников, А.А.Прытков, Л.Г.Фәттахов, А.Г.Хуторов, Х.Г.*Якуповның* әсәрләре В.И.Ульянов-Ленин, Н.Е.Федосеев, М.И.Калинин, М.Вахитовка багышланган. Бөек Ватан сугышы М.Г.*Усманов*, В.А.*Родионов*, Н.М.Сокольский, И.В.*Рәфыйков* иҗатында баталь жанр үсешенә яңа импульс бирә. В.М.*Маликов*, И.А.Новосёлов, Г.А.Зяблицев, В.И.Рогожинның күп кенә монументаль һәм станлы скульптура әсәрләрендә хәрби-патриотик тема ачыла. Скульп. Н.П.Тузов респ-каның район үзәкләрендә мемориаль һәйкәлләр иҗат итә. 1960–80 елларда С.с.т.ж. үсеше образлы чишелешләрнең күптөрлелеге б-н характерлана, аңа «кырыс стиль» дип аталган кысаларда нигез салына. Бәйрәм һәм юбилей көннәре С.с.т.ж.ның алга таба үсешенә уңай шартлар тудыра (Окт. рев-циясе бәйрәме, Җиңү көне, СССР, ТАССР төзелгән көн, КПСС съездлары һ.б., Г.Тукай, М.Җәлилгә һ.б. багышланган респ-ка тематик күргәзмәләре һ.б.). Тарихи вакыйгаларга бәя бирүдә ачык гәүдәләндерелгән героик-романтик концепция В.К.*Фёдоров*, Х.Г.Якупов, Р.М.Вахитов, Ә.Н.Мәҗитов, Р.Ф.*Имашев*, И.К.Әхмәдиев, Е.В.Киселёва, В.П.Аршинов, Н.К.Бикташев, Ш.М.*Шәйдуллин* һ.б.ның тарихи-рев. темага иҗат иткән әсәрләренә хас. В.Н.*Скобеев*, И.К.*Зарипов*, И.В.Рәфыйков, Ш.М.Шәйдуллин, И.М.Хәлиуллов, К.А.*Васильев* һ.б. әсәрләрендәге Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышлары, тылдагы хезмәт батырлыгы темалары символик-аллегорик образларда ачыла. Татар театры тарихы һәм татар иҗат интеллигенциясенең тарихи портретлары (В.К.Фёдоров), Скандинавия эпослары, Борынгы Рус мифлары һәм легендалары (К.К.Васильев), Г.Тукай шигърияте һәм әкиятләре темаларына фантазияләр (Ф.Әминов), борынгы Болгарга багышланган тарихи-көнкүреш композицияләр (К.А.Нәфиков), дөнья тарихы катаклизмнары (И.М.Ханов), ш.у. «Гасыр кешеләре» тарихи-төркемле портрет жанры (А.Ә.*Абызгилдин*) кебек яңа темалар эшләнә. С.с.т.ж. Б.И.*Урманченың* нәкышь, скульптура һәм графика мирасында аерым урын алып тора. Рәссамның тарихи әсәр-истәлекләр фабуласын үткәннәр турында уйланулар, кинаяле сүзләр, гыйбрәтле хикәяләр кисеп үтә. Скульптурада аның тарафыннан образлары беренче тапкыр пластик гәүдәләнеш тапкан күренекле татар мәдәнияте эшлеклеләре: Кол Гали, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Ибраһимов һ.б. бик күпләрнең тарихи портретларыннан торган зур галереясы төзелә. Б.И.Урманче — Яңа Кырлай авылындагы Г.Тукайга багышланган әсәрләренең тупланышы буенча тиңдәше булмаган мемориаль-декоратив комплекс авторы. 1960–80 елларда мемориаль скульптура В.М.Маликов, И.А.Новосёлов, А.Х.*Әбдрәшитов*, Н.И.*Гаделев* иҗатында үсеш ала. Казаннан тыш, Совет хакимияте өчен көрәштә һәлак булган кызылармиячеләргә, Бөек Ватан сугышы солдатларына һәм Советлар Союзы Геройларына һәйкәлләр, Татарстандагы нефть ятмаларын беренче ачучыларга, ш.у. күренекле якташларыбызга монументлар респ-ка шәһәрләренә (Чаллы, Алабуга, Баулы, Менделеевск, Мамадыш, Лениногорск, Болгар һ.б.) һәм авылларына куела. Традицион формалар б-н бергә (һәйкәлләр, бюстлар) архитектур-скульптур композицияләр, стела-рельефлар һ.б. калкып чыкты. Тарихи-мемориаль тема медальләр сәнгатендә И.Н.*Башмаков*, Г.В.Богородская иҗатында чагылыш таба. 1990 еллар С.с.т.ж.ына ил тормышындагы тамырдан үзгәрешләрне чагылдырган тарихка яңача караш хас. Заманнар бәйләнеше, милләтләрнең үз-үзләрен танулары темасы әйдәп баручы урынга чыга. Постмодернизм тарихи үткәннәр чагылышын хисси сагыну күренешләренә әверелдерә. К.А.Нәфыйков, Р.Г.Заһидуллин, Ф.Г.Халиков, Ә.И.Тумашев тарихи пейзаж жанрында борынгы Казан, Болгар, Биләр турында матур мифлар иҗат итә. Борынгы төрки, болгар, мөселман образ-билгеләре Х.М.Шәрипов, А.С.Хәсәнов һ.б. картиналарының сәнгать гармониясен формалаштыра. Табигать көчен җанландыручы фольклор-мифологик образлар (җир, ут, су һ.б. рухы) Ә.С.Фәтхетдиновның нәкышь-скульптур декоратив композицияләре эчтәлеген тәшкил итә. Ш.М.Шәйдуллин ватан (ш.и. Казан) тарихы темасына символик-аллегорик эчтәлектәге монументаль әсәр-




























**Сынлы сәнгатьтә тарихи жанр мәкаләсенә.** 1. К.Б. В е н и г. «Казанны буйсындыру». Эскиз. 19 йөзнең 2 нче яртысы. Дәүләт Рус музее; 2. В.Л. Л а п т е в. «А.П. Щаповның 1861 елның 16 апрелендә Бизнәдә үтерелгән крәстияннәрне искә алу мәрәсим-демонстрациясендәге чыгышы». Эскиз. 1954. ТР Милли музее; 3. Х.Г. Я к у п о в. «Пролог (В.И. Ульянов-Ленин Казан университетында студентлар сходкасында. 1887 ел)». 1967–69. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 4. Л.Г. Ф ә т т а х о в. «Совет властеның беренче елларында». 1967. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 5. Б.И. У р м а н ч е. «Ибне Фазланның Казанга килүе». 1973. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 6. В.К. Ф ё д о р о в. «Е. Пугачёв һәм Б. Канкаев». 1981; 7. А.М. Р о д и о н о в. «Икмәк». 1973–74. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 8. Ш. Н и г ъ м ә т у л л и н. «Җиңеп кайтыгыз». 1997; 9. Ф. Х а л и к о в. «16 йөз Казаны». 1997. «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музее.

ләр тудыра. Тарихи образларның интеллектуаль потенциалы — А.Ә.Абызгилдин иҗатындагы төп тема. Үзенчәлекле тарихи хикмәтләр жанры графикада И.В.Антонованың офортлар сериясендә чагылыш таба. 1990 еллардагы С.с.т.ж.да образлы-стилистик сурәтләү чараларының диапазоны киң: примитивлыкка яраклашкан ялган архаик стильләшү, Коръән аятьләренә сынлы эквивалентлар эзләү; шәмаилләр һәм гарәп каллиграфиясе традицияләре, дөнья сәнгатенең төрле тарихи стильләре рәссамнарның иҗади иреклелеге аша бик теләп файдаланыла. Дингә кайту б-н торгызылучы храмнарда һәм монастырьларда тарихи-дини нәкышь яңара. Монументаль сәнгатьтә С.с.т.ж.на В.Я.Акимов, В.В.Анютин, Ю.Н.Галузина, И.М.Нурмыев, Ю.Г.Свинин һ.б. мөрәҗәгать итәләр.

*Әд.:* Валеева Д.К. Искусство Татарстана. 20 век. К., 1999; Султанова Р.Р. Искусство новых городов Республики Татарстан (1960–1990). К., 2001; Нигматуллина Ю.Г. «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. К., 2002.

*Е.П.Ключевская.*

**СЫҢА́Р ЧӘЧӘ́К** (Moneses), каеш яфракчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Бер төре — эре чәчәкле С.ч. (M.uniflora). Евразиядә, Төньяк Америкада очрый; Татарстанда — Идел-Кама саклаулыгының Раифа участогында һәм Түбән Кама милли паркында. Мүкле, ылыслы урманнарда үсә. 5–10 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы нәзек, шуышма. Сабагы шома, кабыргалы. Яфраклары таралгыда, сабак төбендә тыгыз урнашкан, түгәрәк-йомыркасыман яки түгәрәк формада, төбендә чөйсыман тарайган. Чәчәге сабак очында, берле, иенке, хуш исле. Таҗы ак, киң итеп ачылган. Җимеше — шарсыман тартмачык. Июнь–июльдә чәчәк ата (ел саен түгел). Җимешләре августта өлгерә. Үсемлек тамырларындагы өстәмә бөреләре ярдәмендә яңадан үсеп чыга. Җимеш биргәннән соң, үсемлекнең җир өсте өлеше үлә. Декоратив үсемлек. ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Эре чәчәкле сыңар чәчәк.

**СЫРА́ ҺӘМ АЛКОГОЛЬСЕ́З ЭЧЕМЛЕКЛӘ́Р ҖИТЕШТЕРҮ́ СӘНӘГАТЕ́**, азык-төлек җитештерү сәнәгате тармагы. Татарстанда 4 меңгә якын кеше эшләгән 20 пр-тиене берләштерә (2015). Сыра «Пивоварня Москва-Эфес» (элеккеге «Кызыл Шәрекъ — Солодовпиво» сыра кайнату берләшмәсе, Казан), «Булгарпиво» (Чаллы ш.) АҖҖләре, вак сыра кайнату пр-тиеләре, алкогольсез эчемлекләр «Джонатан», «Кристина» ҖЧҖләре (икесе дә Казанда), «Алиса» алкогольсез эчемлекләр з-ды (Чаллы ш.), *Татарстан Республикасы кулланучылар берлегенең* район һәм шәһәр азык-төлек комб-тларының 14 цехы, сөт комб-тлары һ.б., ясалма һәм натураль минераль сулар «Шифалы су» АҖ (Менделеев р-ны Ижевка а.), «Раифа чыганагы» ҖЧҖ (Казан), «Изыскатель плюс» (Минзәлә ш.) һ.б. тарафыннан эшләп чыгарыла.

Сыра-бал кайнатуның борынгы заманнарда ук булуы мәгълүм. 9 йөздән Русьта салатчылар, колмакчылар, сыра кайнатучылар балдан исерткеч эчемлек әзерлиләр. Беренче эре сыра кайнату з-длары 19 йөз уртасында (С.-Петербург, Мәскәү, Самарада) төзелә, 18 йөз ахырында Казан губернасында кечерәк сыра-бал кайнату з-длары барлыкка килә. 1840 елга кадәр Казанда У.П.Батурин, Г.П.Жадин, Г.С.Мельников, М.С.Щербаков пр-тиеләре, 1867 дә К.Петцольдның тонык сыра кайнаткан «Көнчыгыш Бавария» з-ды (1890 *га* Петцольдлар гаиләсе 3 завод били) ачыла. Төбәк терр-ясендә сыра-бал кайнату з-длары Вятка губернасының Алабуга шәһәрендә (1876 да М.С.Щербаков тарафыннан; соңрак Стахеевлар з-ды), Чистай шәһәрендә (1878, Г.К.Дик; 1880 еллар — А.Я.Бабушкин, А.И.Зезин, Г.К.Маклаков, Мюльгофер, Н.Юрьев), Уфа губернасы Минзәлә шәһәрендә (1881, В.И.Видинеев), салат әзерләү з-ды Зөя шәһәрендә (1886, Г.В.Каменев) нигезләнә. 1892 дә И.В.Александров Казанда зур сыра кайнату һәм салат әзерләү з-ды төзи; 1896 да ул К.Петцольдның бер пр-тиесен сатып ала һәм капиталь ремонт ясый. 1913 тә И.В.Александров (эшләүчеләр саны — 351 кеше; еллык җитештерү күләме — 784 мең чиләк), О.Э.Петцольд (175 кеше; 375 мең чиләк); Г.К.Дик (23 кеше; 30 мең чиләк) варислары Сәүдә йортлары, Алабуга һәм Минзәлә (тиңдәшле рәвештә елга 100 мең һәм 33 мең чиләк) з-длары 1343 мең *дал* сыра җитештерәләр. Г.В.Каменев з-ды 20 мең пот чамасы салат эшләп чыгара. Җирле сыра 1900 дә Парижда (Александров з-ды), 1906 да Флоренциядә (Петцольд з-ды), 20 йөз башында Амстердамда, Бордо, Брюссель, Лондон һәм Парижда (Петцольд з-ды) узган халыкара күргәзмәләрдә медальләргә һәм Гран-прига лаек була.

19 йөзнең 2 нче яртысында Казанда Ф.Г.Грахенның (1855), Т.П.Платуновның (1869), И.В.Александровның (1884) алкогольсез эчемлекләр (лимонад, сидр, җиләк-җимеш сулары, квас, ясалма минераль сулар) җитештерүче пр-тиеләре барлыкка килә (1913 тә алар, ш.у. А.М.Петров з-ды 254 мең сумлык продукция эшләп чыгара). 1899 да өч пр-тие Кисловодск шәһәреннән тимер юл б-н китерелгән «Нарзан» һәм «Ессентуки» минераль суларын бүлеп тутыру б-н шөгыльләнә. 1914 тә *Иж минераль суларын* бүлеп тутыручы АҖ оештырыла.

1917 дә барлык сыра кайнату з-дларының эшчәнлеге туктатыла, 1918–19 да алар национализацияләнә. 1921 дә Казандагы «Нептун» һәм «Химпищ» хезмәт артельләре з-длары (һәркайсында 25 кә кадәр кеше эшли) квас, лимонад, җиләк-җимеш, зельтер (газлы) сулары, содалы су чыгара. 1922 дә эшләмәгән пр-тиеләр җирлегендә Казан «Кызыл Шәрекъ» сыра һәм алкогольсез эчемлекләр з-ды (1941 гә кадәр ТАССР да сыра җитештерүче бердәнбер пр-тие) оештырыла, 1930 да аның каршында алкогольсез эчемлекләр цехы ачыла. Бөек Ватан сугышы чорында сыра эшләп чыгару 2 тапкыр кими, алкогольсез эчемлекләр җитештерү 64% ка арта (1944); Минзәлә сыра кайнату з-ды эшен яңарта. Алдагы елларда Куйбышев (Спас, 1957), Бөгелмә (1959; еллык җитештерү куәте 160 мең *дал*), Тәтеш (1965; 140 мең *дал*), Шәмәрдән (1974; 60 мең *дал*) з-длары файдалануга тапшырыла, Алабуга з-ды эшен яңарта (1963; 270 мең *дал*). 1955 елга, кайнату һ.б. цехлар реконструкцияләнеп, күп кенә технол. операцияләр автоматлаштырылганнан соң, «Кызыл Шәрекъ» з-дында продукция җитештерү күләме (мең *дал*): сыра — 2600, ш.и. сортлы сыра — 304; алкогольсез эчемлекләр — 427, ш.и. квас — 219, җиләк-җимеш сулары — 153, десерт эчемлекләр — 30, лимонад — 25. 1960 та азык-төлек комб-тлары цехлары 506 мең *дал* сыра, 250 мең *дал* алкогольсез эчемлекләр эшләп чыгара. 1970 елларда реконструкцияләр уздырылу нәтиҗәсендә тармак пр-тиеләрендә продукция җитештерү 1,5–2 тапкыр арта. 1970–80 елларда җиһазлар алыштырыла, сыра фильтрлау өчен сепараторлар, алдынгы технологияләр кулланыла башлый. 1975 тә «Кызыл Шәрекъ» з-дында яңа корпусларның елга 7,2 млн. *дал* сыра кайнату куәтле 1 нче чираты, 1978 дә елга 16 мең *т* продукция җитештерүгә сәләтле салат цехы сафка баса; 1970 елларда бүлеп тутыру автомат линияләре урнаштырыла, җитештерелүче продукция сыйфаты б-н идарә итү комплекслы системасы, сыра пастерлау һ.б. үзләштерелә. 1976 да С.һ.а.э.ж.с.нең составына Казан (төп пр-тие), Алабуга, «Минераль сулар» з-длары һ.б. кергән «Кызыл Шәрекъ» ҖБ, 1986 да Татарстан С.һ.а.э.ж.с. ҖБ (1993 кә кадәр) оештырыла. 1981 дә Чаллы (1994 тән «Булгарпиво» АҖ, еллык җитештерү куәте 5,5 млн. *дал*), 1982 дә Түбән Кама (2000 дә 593 мең *дал* сыра, 180 мең *дал* алкогольсез эчемлекләр җитештерә) сыра кайнату з-длары эшли башлый. 1935–90 да респ-ка буенча гомуми җитештерү күләме арту күрсәткечләре (мең *дал*): сыра — 1574 тән 9356 га, алкогольсез эчемлекләр — 939 дан 4974 кә, минераль сулар — 350 дән (1940) 639 га кадәр.

Үзгәртеп корулар һәм икътисади реформалар елларында Минзәлә (1985), Шәмәрдән (1990), Бөгелмә (1997), Тәтеш (1998), Спас (1999), Түбән Кама (2002), Алабуга (2003) з-дларының эшчәнлеге туктала; 1993 тә — «Кристина» газлы эчемлекләр ф-касы (2005 тә 1,3 млн. *дал* күләмендә 25 төрдә алкогольсез эчемлек җитештерә), 1995 тә «Алиса» алкогольсез эчемлекләр з-ды (2005 тә — 4,5 млн. *дал*, ш.и. 1,1 млн. *дал* минераль сулар), 1998 дә «Агропак-Татарстан» алкогольсез эчемлекләр з-ды (еллык җитештерү куәте — 100 мең *дал*; 2005 тән ш.у. елга 50 мең *дал* төрле сорттагы сыра эшләп чыгара) төзелә. 1992–95 тә «Кызыл Шәрекъ» з-дында Америка компаниясеннән кайтарылган концентраттан «Кока-Кола» эчемлеге чыгаралар (елга 100 мең *дал* чамасы), 10 исемдә башка төрле эчемлекләр җитештерелә; алкогольсез эчемлекләр пр-тиенең сатылган продукциясенең 60% ка кадәр өлешен тәшкил итә. Авыл рай-

оннарында алкогольсез эчемлекләр (10 нан артык төрдә) азык-төлек комб-тлары, Әлмәт һәм Түбән Ослан консерв з-длары цехларында эшләп чыгарыла.

1996–2001 дә «Кызыл Шәрекъ» АҖ пр-тиеләрендә Германия һәм Чехия фирмаларының технол. җиһазлары урнаштырыла, җитештерү автоматлаштырыла һәм компьютерлаштырыла, илдә беренче буларак сыраны өч баскычлы фильтрлау технологиясе (пастерламыйча сыраның 6 айга кадәр яраклылыгын тәэмин итә) гамәлгә кертелә. Пр-тиегә халыкара ИСО 9001 сыйфат менеджменты сертификаты бирелә. Еллык сыра һәм салат җитештерү куәте 102 млн. *дал* һәм 105 мең *т* дәрәҗәсенә җиткерелә. 2002 гә сыра эшләп чыгару 17 тапкыр арта һәм елга 41,4 млн. *дал* (2006 да — 23 маркада 16,7 млн. *дал*, яки ТР буенча гомуми күләмнең 90% ы), алкогольсез эчемлекләр 0,4 млн. *дал* тәшкил итә. 2011 дә «Кызыл Шәрекъ» ҖБ «Пивоварня Москва-Эфес» АҖ ф-лы итеп үзгәртелә. Җитештерелгән продукциянең 88% ы Татарстаннан читтә сатыла. 2004–05 тә «Булгарпиво» АҖ заводында продукция җитештерү, бүлеп тутыру һәм саклау юнәлешендә модернизация уздырыла. Пр-тиенең еллык сыра җитештерү куәте 7 млн. *дал* күләменә җитә, продукциянең сыйфаты яхшыра, яңа маркалар үзләштерү мөмкинлеге туа; 2006 да 1,7 млн. *дал* сыра (15 тән артык сорт), 1,3 млн. *дал* алкогольсез эчемлекләр (20 исемдә) эшләп чыгарыла.

Сыра кайнату өчен арпа Курск өлкәсеннән, 1996 дан ш.у. җирле а.х. пр-тиеләреннән китерелә. Колмак Германиядән, Чехиядән һәм Чуаш Респ-касыннан кайтартыла. Алкогольсез эчемлекләр өчен ингредиентларның зур өлеше Австриядән, Германия, Италия, Израиль, Кытайдан һ.б. илләрдән кертелә. Натураль минераль сулар табигый чыганаклардан (Менделеев р-нындагы Ижевка һәм Зәй р-нындагы Ромашкино чыганаклары) алына.

1995–2013 тә сыра җитештерү 3528 дән 24298, алкогольсез эчемлекләр — 2069 дан 4193, минераль сулар чыгару 899 дан 17556 *дал* га кадәр арта. Халыкара һәм бөтенроссия конкурсларында, күргәзмә-ярминкәләрендә респ-ка пр-тиеләре продукциясе күп тапкырлар медальләргә, Гран-при һ.б. бүләкләргә лаек, ш.и. «Булгарпиво», «Алиса», «Агропак-Татарстан» пр-тиеләре чыгарган алкогольсез эчемлекләр төрле елларда «Россиянең иң яхшы 100 товары» конкурсы лауреатлары булалар. Татарстанда җитештерелгән сыраның 16% ы, алкогольсез эчемлекләрнең 60% чамасы җирле базарда сатыла, калган өлеше Россиянең башка төбәкләренә һәм чит илләргә (Германия, Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Украинага) җибәрелә.

Тармак өчен белгечләрне Казан технол. ун-ты, Казан механика-технол. техникумы һ.б. мәгариф учреждениеләре әзерли.

*Әд.:* Фабрично-заводские предприятия Российской империи. П., 1914; Б у ш к о в Р.А., М а з и т о в а Ф.Г. Букет напитков Татарстана. К., 1993; Б у ш к о в Р.А. Казанское пиво // Идель. 1998. № 7.

*М.Җ.Гаитов, С.Г.Белов.*

**СЫРА́Җ**, ш е ш т а м ы р (Scrophularia), сыраҗчалар семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр, сирәк кенә ярымкуаклар ыругы. 150 гә якын (башка мәгълүматлар буенча 300 гә кадәр) төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. ТР терр-ясендә 2 төре — төерле С. (S. nodosa) барлык районнарда очрый, күләгә С.ы (S. umbrosa) — югала баручы төр. Урманнарда, куаклар арасында, болыннарда, яр һәм инеш буйларында үсә. 30–120 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамырчасы бүлбесыман. Сабагы туры, шома, 4 кырлы. Күләгә С.ының сабак кырлары канатлы. Яфраклары озынча-йомыркасыман, пычкы читле, түбәнгеләре — каршыдаш, өскеләре — чиратлашкан. Чәчәкләре вак, яшькелт-коңгырт, себеркәч чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — ике капкачлы күп орлыклы тартмачык. Май–сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре июнь–октябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Төерле С.ның тамырчасы һәм бүлбеләрендә алкалоид, йөрәк гликозидлары, сапонин, органик к-талар бар; халык медицинасында су төнәтмәсе бәвел кудыру, тир чыгару, ялкынсынуга каршы, яра төзәтү чарасы буларак кулланыла. Баллы, агулы үсемлекләр. Күләгә С.ы ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**СЫРАҖЧАЛА́Р** (Scrophulariaceae), ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. Нигездә, бер- һәм күпьеллык үләннәр, сирәк ярымкуаклар, куаклар һәм агачлар. 200 дән артык ыруг һәм 3 меңгә якын төре билгеле, бөтен Җир шарында, күбесенчә Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. ТР терр-ясендә 15 ыруг һәм 59 төр бар. Үләнчел үсемлекләр. Яфраклары чиратлашкан, каршыдаш яки әвернә торышлы, гади, бөтен, төпчек яфраксыз; Пётр әвернәсе яфраклары калын, таңкәсыман. Чәчәкләре ике җенесле, дөрес булмаган формада, оч яки куентылы чәчәк төркеменә, яисә берле һәм яфрак куенында. Касәсе тоташып үскән 4–5 касә яфракчыгыннан тора. Таҗ — тоташ яфракчыклы, көпчәксыман, көпшәле яки калаксыман 4–5 (яушан, сыеркойрык) яфракчыклы, еш кына ике иренле (баллы чәчәк), капчыксыман чыгынтылы яисә нектарлы озын таҗ орысы булган киң кыңгыраулы. Чәчәкләре сары, сирәк кенә шәмәхә. Җимеше — ике капкач б-н ачылучы 2 оялы тартмачык. Орлыклары эндоспермалы. С. арасында ярымпаразитлар (күгәрчен бүреге, күз уты, шөлдерут һ.б.), паразитлар (Пётр әвернәсе), дару (уймак чәчәк, күз уты, саз тубалагы, дарулы бизгәк үләне һ.б.), баллы (төерле сыраҗ, сырлы күз уты, баллы чәчәк), декоратив (шәмәхә чәчәкле сыеркойрык, озын яфраклы яушан, уймак чәчәк), терлек азыгы (яушанның кайбер төрләре) үсемлекләре очрый. Дарулы бизгәк үләне, саз тубалагы, эре чәчәкле уймак чәчәк, күләгә сыраҗ ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**СЫРГАНА́К** (Hippophae), зәйтүнчәләр семьялыгыннан агаччыл үсемлекләр ыругы. 3 төре билгеле, Евразиянең уртача поясында таралган. ТР терр-ясендә 1 төре — эт шомыртысыман С. (H. rhamnoides). Яктылык яратучан культура, салкынга чыдам. Бакча кишәрлекләрендә үстерелә. Куагы яисә агачы 3,5–8 *м* биеклектә, чәнечкеле ботаклы. Яфраклары сызыклы-ланцетсыман, өске ягы соры яшел, аскы ягы көмешсыман. Апрель–майда яфраклары ачылу б-н бер вакытта яисә бераз иртәрәк чәчәк ата. Чәчәкләре бик вак, яшькелт төстә, алтынсыман таңкәләр б-н капланган. Ике өйле үсемлек (ата һәм ана). Җил б-н серкәләнә. Орлыктан, тамырланма ботак һәм үрентеләрдән үрчи. С. үсентеләре утырткannan соң 2–3 елда, ә чәчкеннәре 5–7 елда җимеш бирә башлый. Җимешләре кызыл сары яки кызгылт каты, ян-яклары бераз кысылган, исле, әчкелтем-баллы, озынлыгы 1 *см* га кадәр, август ахырында өлгерәләр, уңышы бер агачтан 8–12 *кг*. Җимешләре дәвалау үзлегенә ия, азык буларак кулланыла; составында шикәр, органик к-талар, каротин, C, P, B витаминнары, серотонин һ.б. биол. актив матдәләр бар, орлыгында һәм җимшәнендә 2,8–9,7% май бар, ул медицинада кулланыла (пешкән, озак ятудан тишелгән урыннарны дәвалаганда, ашказаны җәрәхәте булганда). С. су һәм җил эрозиясе б-н көрәштә туфрак саклаучы үсемлек буларак кулланыла. Тамыр системасы өстә урнашкан һәм күпсанлы үрентеләр барлыкка китерә, алар таралып туфракны ныгыта. Якын торган грунт суларын һәм озак сеңми торган өстәге суларны яратмый. Татарстан шартлары өчен иң яхшы сортлар — «Чуйская», «Золотой початок», «Щербинка 1», «Дар Катуни», «Оранжевая» (1990 елларга кадәр «Масловский», «Түбән Кама» с-зларында үстерелә). Корткычлары — сырганак чебене, сырганак көясе, парсыз ефәк күбәләге һ.б.



*Әд.:* Облепиха. М., 1985; Т р о ф и м о в Т.Т. Облепиха. М., 1988.

**СЫРГАТА́Ш** (Alyssum), әвернә чәчәклеләр семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 150 гә якын төре билгеле, Европа һәм Азиядә таралган. ТР терр-ясендә 4 төре бар. Чүл С.ы (A. desertorum) Кама елгасыннан төньяктарак очрый — читтән кергән үсемлек. Касәле С. (A. calycinum) — Балтач һәм Спас, төрле сабаклы С. (A. diversicaule) — Азнакай, Лена С. ы (A. lenense) Бөгелмә һәм Лениногорск р-ннарында очрый. Барлык төрләре дә известьле көньяк тау битләрендә үсә. Күпсанлы йолдызсыман төкчәле, 5–30 *см* озынлыктагы соры яки соры-яшел күтәрелмә яки ятма сабаклы. Яфраклары йомырка-, ланцетсыман, аскылары — кыска сапларда, өскеләре — утырма. Чәчәкләре күбесенчә сары төстә, чукка җыйналган. Җимеше — ике капкачлы озынча түгәрәк кузакчык. Апрельдән июльгә кадәр чәчәк ата. Орлыктан, ботаклардан үрчи. Халык медицинасында касәле С. — какырык

куптару чарасы. Төрле сабаклы С. — декоратив үсемлек. Касәле С., төрле сабаклы С. һәм Лена С.ы ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**СЫРЛА́Н** (Lappula), кыярчалар семьялыгыннан бер- һәм икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 55 кә якын төре билгеле, күбесенчә Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. ТР терр-ясендә 2 төре бар. Иенке С. (L. patula) — Идел алдының көньяк өлешендә, тырпайган С. (L. squarrosa) респ-каның барлык терр-ясендә очрый. Коры тау битләрендә, елга ярларында, юл буйларында, аланнарда үсә. 10–50 *см* биеклектәге үсемлек. Яфраклары чиратлашкан, кыяк-ланцетсыман, сабагы кебек каты төкчәләр б-н капланган. Җимеше — чикләвекчек, ике рәт эләктергеч б-н капланган, алар исә хайван йонына һәм кеше киеменә ябыша. Шулай итеп җимеше ерак араларга күчә. С. май–августта чәчәк ата. Җимешләре июнь–сентябрьдә өлгерә. Чүп үләннәр.

**СЫРМАВЫ́К** (Asperula), мареначалар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләннәр, ярымкуакчыклар ыругы. 90 га якын (башка мәгълүматлар буенча 200 гә кадәр) төре билгеле, Евразия, Төньяк Америка һәм Төньяк Африкада таралган. Татарстан терр-ясендә 2 төре: кытыршы С. (A. exasperata) һәм кыя С.ы (A. petraea) бар. Кама аръягының көньяк-көнчыгышында очрый. Акбурлы ялангач урыннарда үсә. 5–25 *см* биеклектәге ярымкуакчыклар. Тамырчасы — шушыма. Сабагы шома, 4 кырлы. Яфраклары бөтен, боҗрада. Чәчәкләре вак, ак, кызыл яисә алсу төстә, роберкәч чәчәк төркемендә. Таҗы көпшәле-бүрәнкәле яки кыңгыраусыман. Җимеше — орлыкча. Июнь–августта чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Декоратив, баллы үсемлекләр. Кытыршы С. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**СЫ́РНЕВ** Пётр Яковлевич (16.1.1895, Вятка губ., Нолинск өязе Уни-Лудяны а. — 1955, Казан), терлекләрне үрчетү һәм аларның туклануы буенча белгеч, а.х. фән. д-ры (1938), проф. (1939), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1949). Акад. М.Ф.Иванов шәкерте. Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1921), шунда ук эшли, терлекчелек каф. мөдире (1932–55). Бер үк вакытта, 1931–34 елларда, Сөтчелек хуҗалыгы ин-тында һәм кошчылык буенча зона тәҗрибә станциясендә; 1933–35 тә югары а.х. мәктәбендә, 1933 тән Казан а.х. ин-тында. 1926 һәм 1949 да Татарстанда сарык асраучылыкның торышын өйрәнү буенча оештырылган экспедициягә җитәкчелек итә, 1927–30 да контроль сөтчелек станциясе (Казан) оештыра; шул ук елларда Казан кошчылык комб-тын оештыруда катнаша. Хезмәтләре кошларны карау, ашату һәм симертү технологиясенә; мөгезле эре терлек, сарык, кошларны токым буенча районлаштыру, ш.у. җирле азык ресурслары, сыерларны саву мәсьәләләренә карый. Сыерларның — сөт, сарыкларның йон һәм ит продуктлылыгын арттыру чараларын эшли. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: В помощь коллективному птицеводству. К., 1930; Содержание птицы в колхозных фермах. К., 1944; Выращивание ягнят. К., 1952.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*Ә.Х.Фазылҗанов, М.А.Сушенцова.*

**СЫРТЛА́НОВ** Галиәсгар Шаһхәйдәр улы (1875 — 7.8.1912, С.-Петербург), хокук белгече, җәмәгать эшлеклесе, подполковник. Морзалар нәселеннән, Ш.Ш.*Сыртланов* улы, әнисе ягыннан шәркыятьче галим Х.*Фәезханов* оныгы. Неплюев кадетлар корпусында (Оренбург ш.) укый, Александров хәрби уч-щесен (С.-Петербург) тәмамлаганнан соң, Литва лейб-гвардия полкына кабул ителә. Александр хәрби-хокук академиясен тәмамлаганнан соң (С.-Петербург, 1903), Хәрби министрлыкның Баш хәрби-мәхкәмә идарәсендә хезмәт итә, Петербург хәрби мәхкәмәсендә яклаучы вазифасын башкара. Вице-адмирал З.П.Рождественский, адмирал Н.И.Небогатов һәм генерал-лейтенант А.М.Стессельне рус гаскәрләренең 1904–05 еллардагы рус-япон сугышында җиңелүләрендә гаепләгән шау-шулы процесста адвокат буларак катнаша. 1906 да Киев хәрби прокуроры ярдәмчесе. 1906 ның ахырында хәрби-мәхкәмә ведомствосы запастагы капитаны дәрәҗәсендә отставкага чыкканнан соң, Петербург мәхкәмә округында антлы вәкил. 1907–12 дә 3 нче Дәүләт Думасы депутаты (Уфа губернасының җир милке хуҗалары куриясеннән сайлана), мөселманнар фракциясе әгъзасы; дәүләт оборонасы (секретарь ярдәмчесе), финанс, халыкны күчереп утырту, шәхес кагылгысызлыгы, килештерү комиссияләренә кертелә. «Дәүләт Думасына сайлаулар турында нигезләмәләр»гә («Положения о выборах в Государственную думу») мөселман депутатлар санының кимүенә китергән үзгәрешләр кертелгәннән соң, Дәүләт Думасында чыгыш ясап, хөкүмәт тарафыннан мөселманнарның лояльлегенә бәя бирелмәүне билгеләп үтә һәм әлеге үзгәрешләрнең мөселманнарда гомуми канәгатьсезлек тудыруын әйтә. Петербург мөселманнарының хәйрия җәмгыяте рәисе (1910–12).

Чыг.: Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1917 гг.: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

*Әд.:* С у л т а н б е к о в Б.Ф. История в лицах: Ист.-док. очерки. К., 1997.

*Р.А.Айнетдинов.*

**СЫРТЛА́НОВ** Шаһхәйдәр Шаһгәрдән улы (1847–?), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе. Морзалар нәселеннән. Эре җирбиләүче (2500 дисәтинәдән артык җиргә ия). Неплюев кадетлар корпусын (Оренбург ш.) тәмамлаганнан соң, 9 ел Төркестанда хезмәт итә. 1877 елдан берничә тапкыр Бәләбәй өяз һәм Уфа губерна земстволары гласные итеп сайлана. 1887–91 дә Бәләбәй земство идарәсе рәисе. Уфа губернасыннан 1 нче һәм 2 нче Дәүләт Думасына депутат, мөселманнар фракциясе әгъзасы, 1 нче Думада фракция бюросына кертелә, бюджет һәм аграр комиссияләрдә эшли. Җир биләмәләре талап алынуга басым ясап, башкортларның җиргә ия булу хокукы б-н бәйле мәсьәләләрне күтәрә; фикер алышуларда катнаша һәм кадетлар фракциясе тәкъдим иткән «Гражданнарның тигезлеге турында төп нигезләмәләр» («Основные положения о гражданском равенстве») проектын яклап чыга. Илнең бөтенлеге саклангап хәлдә, Россиянең куәтен ныгыту чыганагы буларак, төпләнеп яшәгән урыннарда барлык милләтләрнең милли-мәдәни үзбилгеләнүе фикерен алга сөрә. 1 нче Дума таратылганнан соң, барлык мөселман депутатлар б-н бергә протест йөзеннән Выборгка китә, ләкин Дума таратылу б-н риза булмаган бер төркем депутатлар тарафыннан кабул ителгән *Выборг өндәмәсенә* кул куймый. Бөтенроссия мөселманнарының 1–3 корылтайларында катнаша (к. *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары*). Мөселманнарның сәяси партиясен оештыру фикерен яклый, булачак партия программасы проектын тикшерү комиссиясенә кертелә. Мөселманнарның 3 нче корылтаенда (1906 ның августы) «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясенең ҮКна сайлана. Уфадагы кадетлар партиясе оешмасы вәкиле сыйфатында кадетлар партиясенең 3 нче съезды (С.-Петербург, 1906 ның апреле) эшендә катнаша; «Иттифакъ әл-мөслимин» конституцион-демократлар партиясенең ф-лы булырга тиеш дигән фикердә тора. Уфа картлар һәм мөселман ир балалар йортының җәмәгать идарәчелеге әгъзасы.

Чыг.: Члены 1-й Государственной думы. М., 1906; Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1917 гг.: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

*Әд.:* Я м а е в а Л.А. Мусульманский либерализм начала XX в. как общественно-политическое движение. Уфа, 2002; Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*Р.А.Айнетдинов.*

**СЫРТЛА́НОВА** (тумыштан Шляхтина) Елизавета Александровна (22.11.1881, Пермь губ., Красноуфимск өязе Суксунский з-ды пос. — 11.12.1961, Уфа ш.), драма актрисасы, БАССРның атказ. артисты (1932). С., башлыча, татар һәм башкорт театр труппаларында эшли, башкорт проф. театры формалашу һәм үсешендә сизелерлек роль уйный. Сәхнә эшчәнлеген 1911 елда Г.Камалның «Бәхетсез егет» пьесасы буенча М.Мутин тарафыннан куелган спектакльдә Гайни роле б-н башлап җибәрә. М.Мутин б-н бергә 1912–15 тә — Уфа шәһәрендә «Нур», 1915–19 да — Оренбургта «Ширкәт» труппаларында, 1919–20 дә Төркестан фронтында фронт театр бригадаларында эшли. 1920–23 тә Уфа, Эстәрлетамак, Екатеринбург шәһәрләрендә Татар-башкорт үрнәк театры актрисасы һәм режиссёры. 1923–25 тә Себер һәм Урал шәһәрләрендә татар һәм башкорт театрлары төзүдә катнаша, 1925–32 дә Бөре, Эстәрлетамак, Баймак, Белорецк, Магнитогорск шәһәрләрендәге татар һәм башкорт театрларында эшли, 1932–33 тә 2 нче Башкорт драма театрының сәнгать җитәкчесе. Татар һәм рус драматургларының пьесалары буенча куелган спектакльләрдә шактый гына зур рольләр башкара: Бәдига («Галиябану», М.Фәйзи), Сәрби («Уйнаш», Г.Камал), Кручинина, Кабаниха, Кукушкина («Гаепсездән гаеплеләр», «Яшенле яңгыр», «Төшемле урын», А.Н.Островский) һ.б. Татар теленә А.Н.Островскийның «Без вины виноватые» («Гаепсездән гаепле-

ләр»), «На бойком месте» («Кеше күп җыелган җирдә»), В.Н.Билль-Белоцерковскийның «Шторм», Н.Градовның «Своим путём» («Үз юлы белән») пьесаларын тәрҗемә итә. Хезмәт Герое (1926).

*Әд.:* Театральная энциклопедия. М., 1965. Т. 4.
*Д.Ә.Гыймранова.*

**СЫРТЛА́НОВА** Мәгубә Хөсәен кызы (15.7.1912, Уфа губ., хәзер БРның Бәләбәй ш. — 1.10.1971, Казан), Сов. Союзы Герое (15.5.1946), гв. өлкән лейтенанты. Аэроклуб (Тбилиси), Тбилиси үзәк планёр мәктәбен (1941) тәмамлый. 1941 елның июленнән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 46 нчы гв. төнге бомбардировщиклар авиация полкының (4 нче һава армиясенең 325 нче бомбардировщиклар авиация дивизиясе) эскадрилья командиры урынбасары. 2 нче Белоруссия фронты авиациясе составында Кавказда (1942–43), Тамань ярымутравында (1943), Кырымда (1944) барган сугышларда, Львов-Сандомир (1944), Көнчыгыш Пруссия һәм Берлин (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1945 нең маена 780 сугышчан очыш ясап, 190 *т* бомба ташлый. Сугыштан соң Казанда яши. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казанда һәм Бәләбәйдә бер урам, Казандагы 52 нче һәм Бәләбәйдәге 2 нче мәктәпләр С. исемен йөртә, Бәләбәйдә С. музее бар, Благовещенск шәһәрендә (Башкортстан Респ-касы) бюст куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.
*М.З.Хәбибуллин.*

**СЫРЬЯ́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 25 *км* төньяктарак, Арбор елгасыннан 1,5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 266 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында С.да чиркәү-приход мәктәбе (1911 дә ачыла), су тегермәне, тимерче алачыгы, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1013,5 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Сизнер волостенда, 1921 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1746 да — 103, 1763 тә — 80, 1811 дә — 75 ир-ат; 1859 да — 132, 1884 тә — 238, 1897 дә — 291, 1905 тә — 324, 1920 дә — 394, 1926 да — 384, 1938 дә — 465, 1949 да — 362, 1958 дә — 291, 1970 тә — 274, 1979 да — 269, 1989 да — 243, 2002 дә — 275 кеше.

**СЫСА́К** Николай Сафронович (5.8.1890, Австрия, Друрин ш. — 30.11.1959, Казан), патологоанатом, мед. фән. д-ры (1959). Вена ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1915), Гменда шәһәрендәге (Австрия) йогышлы авырулар хастаханәсендә эшли. 1917–18 елларда Моравиянең Франкштадт шәһәрендәге ортопедия хастаханәсендә. 1919–21 дә Халыкара Кызыл Хач җәмгыятенең йогышлы авырулар хастаханәсендә (Вена). 1921–24 тә Прагада Патологоанатомия ин-тында. 1924 тә СССР гражданлыгын кабул итә һәм ССР Сәламәтлек саклау халык комис-ты чакыруы буенча Киевка күченә. 1925 тән Киев мед. ин-тының патологик анатомия кафедрасында. 1929 да кулга алына, 1935 тә азат ителә. 1939 дан Казанда, балалар йогышлы авырулары хастаханәсенең патология бүлеге мөдире, 1944–59 да Казан мед. ин-тының нормаль анатомия кафедрасында. Хезмәтләре кеше баш сөягенең яшькә бәйле морфологиясен, травма нәтиҗәсендәге үзгәрешләрне өйрәнүгә карый.

Х е з м.: К вопросу об анатомических изменениях при послетравматической деменции // Тр. Казан. мед. ин-та. 1942. Вып. 1; Об анастомозах артериальных сосудов головного мозга и их практическом значении // Тр. Казан. мед. ин-та. 1957. Вып. 4.
*А.М.Фәйзуллин.*

**СЫСО́ЕВ** Владислав Александрович (7.2.1954, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (2007). 1976 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 2007 дән югары молекуляр материаллар плазмохимиясе һәм нанотехнологияләре каф. профессоры, нанотехнологияләр һәм наноматериаллар ф-ты деканы (2008 дән). Хезмәтләре югары молекуляр кушылмалар химиясенә һәм технологиясенә карый. С. уретан мономерлар һәм олигомерлар синтезлауда, композицион материаллар һәм алар нигезендә коррозиягә каршы торучан капламнар, ш.у. табигый югары молекуляр кушылмаларны структур модификацияләүнең плазмалы алымнарын, тире һәм күн эшкәртүдә хром саклаулы дуплау процессы технологияләрен эшләүдә («Мелита» АҖдә гамәлгә кертелгән) катнаша. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Взаимодействие органических карбонатов с аминами // Журн. орган. химии. 1983. Т. 19, № 3 (автордаш); Синтез уретангликолей // Журн. прикладной химии. 1999. Т. 72, вып. 10 (автордаш); Перспективы развития хромсберегающих технологий при выделке кожи и меха // Кожевенно-обувная пром-сть. 2004. № 1 (автордаш).

**СЮМСИ́ РАЙОНЫ́**, *Удмурт Республикасының* көнбатыш өлешендә урнашкан. 1929 елда оештырыла. Мәйданы — 1792,3 *км*². Үзәге — Сюмси авылы (Ижевскидан 140 *км* көнбатыштарак). Халкы — 13038 (2013), татарлар — 448 кеше (2010). Татарлар, башлыча, Көлмез (2008 дә — 275 кеше) һәм Муки-Какси (106) авылларында яшиләр. Район терр-ясенә татарлар 1940–50 елларда Сюрек урман сәнәгате хуҗалыгы (1942 дә оештырыла) эшчәнлеге б-н бәйле рәвештә күченәләр һәм монда агач әзерләү б-н шөгыльләнәләр.

**СЮНЯ́ЕВ** Заһидулла Исхак улы (10.12.1929, Мордва АССРның Атюрьев р-ны Татар Виләзмәсе а. — 2001), нефтехимик, техник фән. д-ры (1970), проф. (1970), БАССРның, РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1967, 1974), БР ФАнең шәрәфле академигы (1991). Мәскәү нефть ин-тын тәмамлый



М.Х.Сыртланова.



Р.Г.Сюняев.

(1953). 1953–62 елларда Яңа Уфа нефть эшкәртү з-дында эшли (Уфа ш.). 1962–76 да Уфа нефть ин-тында: нефть һәм газ эшкәртү технологиясе каф. мөдире (1962–76), ректор (1970 тән). 1976 дан И.М.Губкин исем. Дәүләт нефть һәм газ академиясендә (Мәскәү): нефть һәм газ каф. мөдире (1976–98), проф.-консультант (2000 нән). Хезмәтләре нефтьле дисперс системаларга һәм нефть эшкәртү технологиясенә карый. С. нефть системаларының чыгару, ташу һәм эшкәртү процессындагы физик-химик үзлекләре б-н аларның дисперс төзелеше арасында бәйләнеш турындагы теоретик күзаллауларны үстерә, «нефтьле системаның экстремаль халәте» төшенчәсен кертә. Яңа нефть продуктлары: югары сыйфатлы кокслар, пеклар, чәчелүчән материалларның ябышуына һәм өшеп катуына каршы профилактик чаралар, мотор ягулыклары һ.б. табуның технол. процессларын эшли һәм җитештерүгә кертә. СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге лауреаты (1996). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Замедленное коксование нефтяных остатков. М., 1967; Производство, облагораживание и применение нефтяного кокса. М., 1973; Нефтяной углерод. М., 1980; Дисперсные состояния в каталитических системах нефтепереработки. М., 1992.

**СЮНЯ́ЕВ** Рәшит Гали улы (1.3.1943, Ташкент), астрофизик, физика-матем. фән. д-ры (1973), РФА академигы (1992; 1984 тән СССР ФА мөхбир әгъзасы). 1966 елда Мәскәү физика-техника ин-тын тәмамлый. 1968–74 тә СССР ФАнең Гамәли математика ин-тында. 1974 тән РФАнең Космик тикшеренүләр ин-тында (Мәскәү): теоретик астрофизика лаб-ясе мөдире (1982 гә кадәр), югары энергияләр астрофизикасы бүлеге мөдире (1982–2002), проф. (1987), баш фәнни хезмәткәр (2002 дән). Бер үк вакытта, 1996 дан, Макс Планк исем. җәмгыятьнең Астрофизика ин-ты идарәче директоры (Гархинг ш., Германия). Хезмәтләре югары энергияләр астрофизикасына, космологиягә, Галәмнең фонлы нурланышына, галактикаара тирәлек физикасына карый. С. нурланыш һәм плазманың үзара тәэсирен экстремаль астрофизик шартларда: беренчел Галәмдә, рентген нурланышының җыйнак чыганакларында, галактика төшләрендә һәм квазарларда тикшерә. Кара тишекләрне һәм матдәләр аккрециясе хисабына нурландыра торган нейтрон йолдызларны (релятивистик йолдызлар) эзләү һәм тәңгәлләштерү алым-

нарын тәкъдим итә. Релятивистик йолдызларга дисклы аккреция теориясен эшли. Рентген пульсарлары — көчле магнит кырлары булган нейтрон йолдызларның нурланыш спектрында циклотрон сызыклар булуын алдан әйтә. Нейтрон йолдызларның магнит полюслары янындагы кайнар тап нурланышы юнәлешенең диаграммасы формалашуын тикшерә, чыккан нурланышның полярлашуын һәм аның спектрын исәпли. Рентген пульсарлары импульсларының формалашуы модельләрен тәкъдим итә, нейтрон йолдызлар өслегендә термотөш януы фронтының таралуын тикшерә. Куш рентген системаларын оптик эзләү алымнарын тәкъдим итә һәм бу объектларның регуляр оптик үзгәрүен күзәтүләр нәтиҗәсен фәнни аңлата. Рентген нурланышы б-н гадәти йолдыз атмосферасының үзара тәэсир итешүен: йолдыз өслегеннән матдәнең парга әйләнүе, рентген нурларының кайтарылуы, атмосфераның җылынуы һәм шул сәбәпле йолдыз өслегендә кайнар тап хасил булуны тикшерә. Галәмдә водород рекомбинацияләре кинетикасын исәпли, бу процессның тигезләнешледән читкә тайпылулары нәтиҗәсендә мөһим астрофизик күренешләр килеп чыгуын күрсәтә. Галактикалар тупланышы юнәлешендәге реликт нурланышның яктыртылу темп-расы түбәнәюен алдан әйтә (Зельдович-Сюняев эффекты), һәм бу газ болытының үлчәмнәрен, болытка кадәр ераклыкны һәм аның фон нурланышына карата хәрәкәт тизлеген билгеләү мөмкинлеген бирә (үз чиратында Хаббл константасын һәм Галәмнең яшен билгеләү мөмкинлеге туа). Галактикалар тупланышындагы һәм өр-яңа йолдызларның балкыш калдыкларындагы кайнар газга диагностика үткәрү алымын тәкъдим итә (1984). Реликт нурланышның почмакча бүленешендә доплер пиклары барлыгын алдан әйтә (2000 дә экспериментта табыла). 1980 елларда «Салют-7» орбиталь станциясендә компактлы галактик чыганакларның каты рентген нурланышын күзәтүче «Прогноз-9» иярчелендә космик гамма-балкышларны тикшерүнең һ.б.ның фәнни җитәкчесе була. «Письма в астрономический журнал» (1985 тән) һәм «Astrophysics and Space Physics Reviews» (1979–2003) ж-лларының баш мөхәррире. Халыкара фәнни берләшмәләр советының Космик тикшеренүләр комиссиясе вице-президенты (КОСПАР, 1988–94), Америка астрономия җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы (1990 нан), Европа астрономия җәмгыятенең вице-президенты (1991–93), Бөекбритания Корольлек астрономия җәмгыятенең чит ил әгъзасы (1994 тән), Филадельфия шәһәрендә Америка философия җәмгыятенең чит ил әгъзасы (2007 дән), Халыкара астрономия берлеге (1986 дан), Европа астрономия җәмгыяте (1991 дән) әгъзасы. РФ Дәүләт бүләге лауреаты (2000). Халыкара астронавтика академиясе (1990), РФАнең гравитация һәм космология буенча Александр Фридман исем. (2002), П.Грубер фонды һәм Халыкара астр. берлегенең космология буенча П.Грубер исем. (2003), Швеция Корольлек ФАнең астрономия буенча Х.Крафурд исем. (2008), Согуд Гарәбстаны короле Фейсалның Халыкара (2009) һ.б. бүләкләр лауреаты. Медальләр, ш.и. чит илләр астрономия җәмгыятьләре һәм берлекләренең алтын медальләре б-н бүләкләнә. АКШ Милли ФАнең чит ил әгъзасы (1991 дән), Америка Фәннәр һәм сәнгать академиясенең шәрәфле әгъзасы (Бостон ш., 1992 дән). БР ФАнең шәрәфле әгъзасы (1992 дән), ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы (1995 тән), Людвиг Максимилиан исем. ун-тның шәрәфле профессоры (Мюнхен ш., 1999 дан), Казан ун-тының шәрәфле профессоры (2000 нән).

Х е з м.: The interaction of matter and radiation in a hot — model universe // Astrophys. and Space Sci. 1969. V. 4, № 3 (автордаш); Small — scale fluctuations of relic radiation // Astrophys. and Space Sci. 1970. V. 7, № 1 (автордаш); Black holes in binary systems. Observational appearance // Astron. Astrophys. 1973. V. 24 (автордаш); Microwave background radiation as a probe of the contemporary structure and history of the universe // Ann. Rev. Astron. Astrophys. 1980. V. 18 (автордаш).

**«СЮРЛО́»** («Урак»), иҗтимагый-сәяси газета. Алабуга өязе крәстиян депутатлары советының удмурт бүлекчәсе органы. 1920 елның 17 июленнән 1921 гә кадәр Алабугада удмурт телендә нәшер ителә.

# Т

**ТАБА́Н БАЛЫКЛА́Р** (Carassius), карплар семьялыгыннан төче су балыклары ыругы. 2 төрне үз эченә ала: гади яки алтын Т.б. (C. carassius) һәм көмеш Т.б. (C. auratus). Озынлыгы 45 *см* га, авырлыгы 3 *кг* га кадәр. Биек аркалы, сырты кара көрән төстә, ян-яклары көмешсыман. Сырт йөзгече озын, сырт һәм арткы йөзгечләрендә теш-тешле чәнечкеле нурлар бар. ТРда ике төре дә очрый. Көмеш Т.б. Көнчыгыш һәм Урта Европа, Себер терр-ясе сулыкларында (Лена елгасына кадәр) яши; Көнбатыш Европа климатына яраклаштырылган. ТР күл һәм буаларында киң таралган. Кәсәбәчелек әһәмияте зур. Кислород җитешмәвен җиңел кичерә. Башка кыйммәтле балыкларның тереклеге өчен яраксыз сай һәм үлән баскан сулыкларда яшиләр. Яшәвенең 4–5 нче елында җенси җитлегә. Май–июньдә уылдык чәчә. Үрчемлелеге — 9 меңнән 190 (кайвакыт 300) меңгә кадәр



Алтын табан балык.

уылдык бөртеге. Планктон, су төбе хайваннары, бөҗәк личинкалары, суүсемнәр б-н туклана. Көмеш Т.б. Европа (Швеция һәм Финляндия), Себер сулыкларында яши; Һиндстан һәм Төньяк Америка климатына яраклаштырылган. ТРда аз агымлы һәм үсемлекләр күпләп үскән сулыкларда очрый. Көмеш Т.б.ның 2 астөренең берсе (C.a. auratus) аквариум алтын балыгының һәм аның төрчәләре: телескоп, җилпәзә-койрык һ.б.ның беренче формасы булып тора. Яшәвенең 2–3 нче елында җенси җитлегә. Үрчемлелеге — 160–380 мең уылдык бөртеге. Уылдыгын үсемлекләргә сала. Көмеш Т.б. өчен гиногенез хас (ата затлар булмаган колонияләр очрый, һәм уылдыгы тугандаш төрдәге башка балыклар б-н аталана). Ике төре дә буаларда балык үрчетү өчен файдаланыла.

**ТАБАНЛЫ́ КҮЛ** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 44 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сикия елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 169 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1772 гә кадәр нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.К.да мәчет, мәктәп эшли. 1913 тә авыл җәмәгатенең имана җире 1998 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Уфа губернасының Минзәлә өязе Әмәкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 86 кеше, 1816 да — 46 ир-ат; 1834 тә — 1129, 1859 да — 236, 1870 тә — 263, 1884 тә — 407, 1897 дә — 441, 1906 да — 525, 1913 тә — 650, 1920 дә — 652, 1926 да — 545, 1938 дә — 518, 1949 да — 380, 1958 дә — 264, 1970 тә — 387, 1979 да — 240, 1989 да — 154, 2002 дә — 177 кеше.

**ТАБА́Р** елгасы, Идел алдында, Үләмә елгасының (Зөя елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 22,6 *км*. Бассейнының мәйданы 84,8 *км*$^2$. Идел буе калкулыгыннан, Апас р-нында ага. Елга башы Төбәк Черкене авылыннан 2 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Чүри-Бураш авылыннан көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 190 *м*, тамагыныкы — 72 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. Т.ның 0,6 дан 4,6 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,37 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Җәйге айларда, озак вакыт яңгырлар яумаганда, елга урыны-урыны б-н кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 110 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренчеункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,03 *м*$^3$/с. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада суының күләме 1,1 млн. *м*$^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ТАБА́Р ЧЕРКЕНЕ́** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 9 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 419 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1721 гә кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Ч.ндә Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1893 тә ачыла), 3 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 804,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Ильинка-Шонгат волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 65 ир-ат; 1859 да — 259, 1897 дә — 700, 1908 дә — 726, 1920 дә — 814, 1926 да — 589, 1938 дә — 688, 1949 да — 464, 1958 дә — 505, 1970 тә — 493, 1979 да — 515, 1989 да — 454, 2002 дә — 495 кеше.

**ТАБИГА́ТЬ АФӘТЛӘРЕ́**, халыкның гадәти яшәү эшчәнлегенең җимерелүенә, кеше үлеменә һәм матди байлыкларның юкка чыгуына китерүче гадәттән тыш табигать күренешләре һәм процесслары. Т.а., кагыйдә буларак, кинәт барлыкка килүләре, шактый зур масштабта һәм төрле дәвамлылыкта (берничә секунд һәм минуттан берничә көн, айга кадәр) булулары б-н сыйфатланалар.

Корбаннар саны 4 һәм артыграк, зыян күрүчеләр 10–15 кеше һәм артыграк, матди зыян 0,5 млн. сумнан артыграк (1992 елгы бәяләрдә) булганда (шушы шартларның берсе генә күзәтелсә дә), Россиядә куркыныч табигый һәм техноген күренешләр гадәттән тыш хәл дип атала. Геофизик (*җир тетрәүләр*, вулкан атылу), геол. (*шуышмалар*, ярсулы агым, ишелмәләр һ.б.), метеорологик (буран, гарасат, өермә, шкваллар, эре боз яву, *корылык*, *кырау*, ком давылы, көчле суык, эсселек, кар яву), гидрологик (*су басулар* һ.б.), биол. (а.х. культуралары корткычлары һәм авыруларының күпләп үрчүе, биотөрлелекнең кимүе) һәм антропоген (табигый мохитнең пычрануы, урманнарның бетүе, чүлгә әйләнү, туфракның тозлануы һәм эрозиясе, урман һәм торф янгыннары һ.б.) Т.а.нә аерып йөртәләр. Татарстан терр-ясендә куркыныч табигать күренешләренә су басулар, кар бураны, ком давылы, корылык, өермә, боз яву һ.б. керә. 55 еллык күзәтүләр эчендә (1950–2004) Казан р-нында көчле җил (җилнең тизлеге 25 *м/с* һәм артыграк) һәм көчле буран (җилнең тизлеге 15 *м/с* һәм артыграк, күз күреме 500 *м* дан артык түгел, дәвамлылыгы 12 *сәг.* тән ким булмаган) уртача 3 елга 1 тапкыр, бик көчле яңгыр (1 *сәг.* чамасы вакыт эчендә 30 *мм* дан ким түгел) — 5 елга 1 тапкыр, яңгыр (12 *сәг.* эчендә 50 *мм* дан ким түгел) — 14 елга 1 тапкыр һәм кар (12 *сәг.* эчендә 20 *мм* дан ким түгел) 6 елга 1 тапкыр билгеләнә. Барысыннан да сирәгрәк көчле суыклар (40 °C һәм түбән) — 18 елга 1 тапкыр һәм эсселек (38 °C һәм югары) барлык күзәтү чорында 1 тапкыр була. Җылы яратучан культура чәчкеннәре һәм үсентеләре, җиләк-җимеш культураларының чәчәк җимшәннәре өчен куркыныч тудыручы соң килгән язгы һәм иртә көзге кыраулар аеруча еш (елга 1–2 очрак) күзәтелә. Көчле җилләр һәм өермәләр корылмаларны җимерә, урман хуҗалыгына шактый зыян китереп, агачларны аудара (1979, 2000). Көчле яңгыр һәм боз чәчүлек-

ләрне бетерә. Көчле кар яуганда һәм бураннарда транспорт эше катлауланa, транспорт-юл һәлакәтләре арта.

2010 елның апреленнән августка кадәрге чорда Россиянең үзәк р-ннарына, ш.у. Идел һәм Урал буена гадәттән тыш корылык килә, атм. һавасының темп-расы аномаль югары була. Гомумән явым-төшемсез июль–августта ул 40 °С ка (1 август) күтәрелә. Бу а.х. культуралары уңышының нык кимүенә, ә күп кенә төбәкләрдә (Мордва, Мари, Чуаш респ-каларында һ.б.) урманнарда һәм торфлыкларда янгыннар чыгуга китерде.

1960 еллар б-н чагыштырганда 21 йөз башына Җирдә табигать бәла-казалары 3 тапкыр арта. Дөньяда алар нәтиҗәсендә ел саен 75–86 мең кеше үлә, зыян күрүчеләр саны 1,5–2,1 млрд. кешегә җитә. 2050 гә хәтәр табигать күренешләреннән килгән зыян 300 млрд. долларга җитәчәк дип көтелә, бу сумма исә гомуми тулай продукт артымының яртысы диярлек. Җәмгыятьнең иминлеген ныгыту проблемасы тулы бер чаралар комплексын эшләүне таләп итә; аеруча мөһимнәре: куркыныч һәм җимергеч табигый һәм техноген процесслар б-н көрәштә өстенлекләрне билгеләү; кисәтү һәм чара күрү системаларын булдыру; хәтәр табигать процесслары була торган р-ннардагы терр-яләрне хуҗалыкчан куллануны көйләү буенча закон актлары һәм норматив документлар эшләү.

Т.а.н булдырмый калу мөмкин түгел, әмма алдан әйтү, вакытында халыкка хәбәр итү һәм тиешле саклык һәм саклану чаралары күрүгә юнәлтелгән чаралар үткәргәндә күңелсез нәтиҗәләрне шактый киметергә мөмкин. Татарстанда бу функция ТР Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына (1995 тә оештырыла) йөкләнгән.

*Әд.:* Климат Казани и его изменения в современный период. К., 2006.

*Ю.П.Переведенцев, Э.П.Наумов.*

**«ТАБИГА́ТЬ ЕЛЪЯЗМАСЫ́»**, саклаулык экосистемалары торышы турында мәгълүматны хронологик тәртиптә туплаучы документ. Исеме 1937 елда Мәскәү ун-ты проф. А.Н.Формозов тарафыннан тәкъдим ителә. Саклаулыкларда фәнни тикшеренүләр методологиясен эшләүдә Россиянең танылган экологлары катнаша, аеруча Г.А.Кожевников зур роль уйный. Татарстан терр-ясендә «Т.е.» 1962 дән Идел-Кама саклаулыгында алып барыла. Ул табигать экосистемалары эволюциясенең үсеш закончалыкларын һәм юнәлешләрен тикшерергә, антропоген тәэсиргә дучар булган төбәк кысаларында уздырылган экологик тикшеренүләр вакытында саклаулыкларны эталон буларак файдаланырга, табигатьтән нәтиҗәле файдалануның һәм табигатьне саклауның фәнни ысулларын эшләргә мөмкинлек бирә. «Т.е.» программасы буенча эшне экологик мониторинг алып бара, аның нәтиҗәләре еллык «Т.е.» китабында бирелә. Анда саклаулыкның физ.-геогр. шартлары, флора, фауна, һава торышы, табигать календаре, саклаулык режимының торышы һ.б. турында мәгълүматлар китерелә. 1990 еллардан «Т.е.» геогр. мәгълүматлар системасы һәм компьютердагы мәгълүматлар нигезендә алып барыла.

*Әд.:* Ф и л о н о в К.П., Н у х и м о в с к а я Ю.Д. Летопись природы в заповедниках СССР. М., 1985.

*О.В.Бакин.*

**ТАБИГАТЬНЕ́ САКЛА́У**, табигый байлыкларны саклау һәм торгызуны тәэмин итүче, кеше эшчәнлеге һәм әйләнә-тирә мохит арасында рациональ бәйләнеш тотуга, ш.у. кешелекнең киләчәктәге үсеше өчен яңадан торгызып булмаслык табигать байлыкларын экономияләүгә юнәлтелгән чаралар системасы (технологик, икътисади, адм.-хокукый, иҗтимагый-сәяси, танып-белү һ.б.). Т.с.ның мөһим принциплары: профилактиклык (негатив нәтиҗәләрне кисәтүгә юнәлтелә), комплекслылык, һәр җирдә терр. дифференциальлек, фәнни нигезлелек. Т.с., *табигатьтән файдалануның* бер өлеше буларак, табигый байлыкларны рациональ файдалану б-н тыгыз бәйләнгән. 20 йөз урталарыннан сәнәгатьнең интенсив үсеше, шәһәрләрнең үсүе, халык санының артуы һ.б. факторларга бәйле рәвештә Т.с. глобаль проблемага әйләнә, кешенең табигатькә йогынтысы кинәт көчәя, табигать байлыклары бетү куркынычын тудыра, гомумән биосфераның һәм *әйләнә-тирә мохитнең пычрануына* китерә. Шул сәбәпле халыкара оешмалар һәм проектлар төзелә: дөньяның 125 илендәге 800 дән артык оешманы эченә алган Халыкара табигатьне саклау берлеге (1948), «Әйләнә-тирә мохит буенча БМО программасы» («Программа ООН по окружающей среде», ЮНЕП), анда 58 дәүләт катнаша (1972), «Кеше һәм биосфера» («Человек и биосфера», 1971) ЮНЕСКО программасы, «Бөтендөнья табигатьне саклау стратегиясе» («Всемирная стратегия охраны природы», 1979), «Җир хартиясе» («Хартия Земли», 1995) һ.б.; Т.с. өлкәсендә дәүләтләрнең уртак гамәлләрен тикшерү һәм координацияләү буенча күпсанлы халыкара конвенцияләргә һәм килешүләргә кул куела. Татарстанда Т.с.ның барлык төп юнәлешләре: җылылык-энергетика, минераль чимал һ.б. матди байлыкларны комплекслы куллануда пр-тие һәм оешмаларның җаваплылыгын арттыру; туфракның, су чыганакларының һәм атм. һавасының пычрануын булдырмау, ш.у. әйләнә-тирә мохитне саклауда гражданнарның җаваплылыгын арттыру һ.б. буенча чаралар үткәрелә. Респ-ка икътисады ныгуга бәйле рәвештә Т.с.га күбрәк игътибар юнәлтелә, бу ТР Президентының ТР Дәүләт Советына еллык юлламаларында, ТР Дәүләт Советының тиешле закон актларында, ТР МКның гамәлдәге законнарга нисбәтле норматив-хокукый документларында, Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының еллык «Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый ресурслар торышы турында» дәүләт докладларында, ш.у. аерым программаларны, проект һәм чараларны финанслауда чагылыш таба. Респ-када *аеруча саклаулы табигать территорияләре һәм акваторияләре* оештыру киң үсеш ала. Алар 40 муниципаль район терр-ясендә, ш.у. Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә урнашкан: *Идел-Кама саклаулыгы* (1960 та оештырыла, 2005 тә ЮНЕСКОның биосфера резерваты статусын ала), *«Түбән Кама милли паркы»* (1991), 24 дәүләт табигать тыюлыгы, 121 табигать һәм 1 тарих-архит-ра истәлеге, төбәкара әһәмияткә ия табигать терр-ясе. Аларның гомуми мәйданы 92,7 мең *га* (ш.и. коры җирдә 92,3 мең *га*) яки ТР терр-ясенең 2% ын тәшкил итә. ТРның *Кызыл китабы* (1995; 2 басма, 2006) Т.с. системасында һәм биомониторингта мөһим урын били. Соңгы елларда хайваннарның — 6, үсемлекләрнең 98 төре китаптан чыгарылды, имезүчеләр, кошлар һәм умырткасызларның 69 төре (41% ы) респ-када тереклек ареалын киңәйтте.

ТРда Т.с. функцияләрен дәүләт идарәсенең махсус органнары башкара: Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы, Урман хуҗалыгы министрлыгы, А.х. һәм азык-төлек министрлыгы, Төзелеш, архит-ра һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Сәламәтлек саклау министрлыгы, Эчке эшләр министрлыгы, Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һ.б. респ-ка органнары, ш.у. федераль терр. органнар: ТР буенча Табигатьтән файдалану өлкәсен тикшерү федераль хезмәт идарәсе, РФ Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының ТР буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану идарәсе һ.б. ТР Дәүләт Советында Экология, табигый байлыклар һәм җирдән файдалану тәртибе ком-ты оештырыла, ТР Дәүләт Советы Аппараты составында Экология, табигый байлыклар һәм җирдән файдалану тәртибе буенча ТР Дәүләт Советы ком-ты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге, ТР МК Аппараты составында табигатьтән файдалану һәм экология бүлеге булдырыла.

Т.с. өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый көйләү җир, су, тау, урман, сәламәтлек саклау һ.б. федераль һәм респ-ка законнары б-н алып барыла. 2004 елда ТРның «Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Законы кабул ителә, ул җәмгыять һәм табигатьнең үзара бәйләнешләре өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

Татарстанда Т.с. проблемаларына караган фәнни-тикшеренү эшләрен РФАнең КГУ, ТР ФАнең фәнни-тикшеренү учреждениеләре, ун-тлар һ.б. югары уку йортлары, ш.у. Идел-Кама саклаулыгы, «Түбән Кама» милли паркы алып бара. Табигать системаларын нәтиҗәле куллану өлкәсендәге төбәк тикшеренүләрен ТР ФАнең Экология һәм табигать системалары ин-ты (1993 тә оештырыла) координацияли. Т.с. проблемаларына караган фундаменталь һәм гамәли фәнни тикшеренүләрне координацияләү һәм галимнәр туплауның нәтиҗәле формасы — ТР ФА президиумы каршындагы Экология проблемалары буенча гыйльми совет. Фәндә һәм тормышта зур әһәмияткә ия экология һәм табигатьне рациональ файдалану өлкәсендәге фәнни хезмәтләр өчен 2003 тә ТР ФА, ТР Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы һәм Казан ун-тының проф. В.А.Попов исем. бүләге булдырыла. В.А.Попов — СССРда беренче табигатьне саклау каф. мөдире (1969), аның

җирлегендә 1989 да илдә беренче экология ф-ты ачыла. Т.с. нигезләре гомуми белем бирү мәктәпләре, техникум, югары уку йортларының уку программаларына кертелгән.

Халык арасында табигать турындагы белемнәрне пропагандалау аерым әһәмияткә ия, бу эш б-н «Руфь» экология телерадиостудиясе (1998), «Региональная экологическая газета» (1999), иҗтимагый оешмалар: Бөтенроссия табигатьне саклау җәмгыятенең Татарстан респ-ка оешмасы, Татарстан Респ-касының Яшьләр экологик хәрәкәте (Ф.Мөхәммәдиева исем. Табигатьне саклау берләштерелгән дружинасы, Казан ун-тының «Табигатьне саклау хезмәте» дружинасы, Казан технология ун-тының табигатьне саклау дружинасы һ.б.), респ-ка «Яшел планета» балалар экологик хәрәкәте, «Табигать дуслары берлеге» балалар оешмасы (Чаллы ш.), студентларның «Экодос» ирекле экологик җәмгыяте (Алабуга ш.), «Экозаман» табигать сөючеләр клубы (Менделеев ш.), Бөтенроссия табигатьне саклау җәмгыяте Татарстан респ-ка берлегенең Әлмәт һәм Чаллы иҗтимагый оешмалары һ.б. шөгыльләнә.

Татарстан Респ-касы Т.с. буенча федераль һәм халыкара оешмалар эшендә актив катнаша. 2001 дә ТР Дәүләт Советының «Җир хартиясе турында» махсус карары кабул ителә. Татарстан — дөньяда Хартия принципларын гамәлдә кулланучы беренче төбәк, әлеге принципларны тормышка ашыру төбәкнең тотрыклы үсеше буенча халыкара проект формалаштыруга юнәлтелә, ә моңа исә әйләнә-тирә мохитне һәм кешене тискәре табигать күренешләреннән һәм антропоген йогынтылардан саклау дәрәҗәсен күтәрми ирешү мөмкин түгел.

*Әд.:* Экология: безопасность нации. К., 1998; Экология и охрана природы: Словарь-справ. М., 2000; Государственный доклад о состоянии природных ресурсов и об охране окружающей среды Республики Татарстан в 2005 году. К., 2006; Красная книга Республики Татарстан. К., 2006.

*Н.Х.Газиев.*

**ТАБИГАТЬТӘ́Н ФАЙДАЛАНУ́**, табигый байлыклар ярдәмендә кешелек ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлтелгән иҗтимагый-җитештерү эшчәнлеге өлкәсе. Т.ф. нигезле булганда, яңадан булдырыла торган байлыкларны кабат торгызу, үсеш алган халык хуҗалыгының һәм кеше сәламәтлегенең киләчәк ихтыяҗларын исәпкә алып, яңадан булдырылмый торган байлыкларны экономияле чыгару һәм тоту; уңай тереклек мохитен, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының, ландшафтның төрлелеген саклау; зарарлы калдыкларны куркыныч тудырмаслык итеп күмү эшләре алып барыла. Табигатьтән рациональ файдалануга экология дә керә (к. *Табигатьне саклау*); рациональ файдаланмау исә табигый байлыкларның тотылып бетүенә, табигатьнең яңадан торгызылу көчләренең какшавына, аның сәламәтләндерү һәм эстетик сыйфатлары кимүгә китерә. Бу табигый мохит б-н аерым бер җирлектә, төбәктә, ә 20 йөзнең 60 елларыннан гаять зур масштаблардагы үзара тәэсир итешүдә киеренкелек, каршылык тудыра. 20 йөз урталарыннан башлап табигатьтә бара торган процессларның гармониясен саклау максатында Т.ф.ны идарә итү кирәклеген аңлау ныгый (идарә итүдә төп роль дәүләттә кала). Т.ф. өлкәсендә дәүләтнең төп көйләү функцияләре: нигезле файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча нормалар эшләү; әлеге өлкәдә оештыру эшчәнлеге, ш.и. планлаштыру, финанслау, лицензия бирү; әйләнә-тирә мохит мониторингы, табигатьне саклау законнарының үтәлешенә күзәтчелек һәм контроль.

ТРда Т.ф.ның үзенчәлекләре респ-каның бай табигый ресурслар базасы: яхшы агроклиматик, су, туфрак-үсемлек һәм ландшафт, балык һәм сунарчылык ресурслары, минераль һәм төзелеш материаллары, янучан файдалы казылмалар, аграр рудалар б-н бәйле (к. *Табигый байлыклар*). Төбәкнең тулай продукты үсешен һәм халыкның тормыш дәрәҗәсен яхшыртуны тәэмин итүче табигый чимал ресурсларын һәм төбәкнең табигый ресурс потенциалын макс. дәрәҗәдә нәтиҗәле куллану респ-каның социаль-икътисади үсешендә төп максат булып тора. Нефть — төбәкнең төп табигый ресурс базасын төзүче. Аны чыгару буенча ТР РФ субъектлары арасында — 2 нче, дөньяда 32 нче урынны алып тора. Россиядә чыгарылучы табигый битумның 36% ы диярлек Татарстан терр-ясендә. Респ-када җирдән файдалану (җир фондының төп өлеше — 70% ка якыны — а.х. җирләренә туры килә) һәм игенчелек культуралары югары дәрәҗәдә: бөртек, ит, сөт һ.б. продукция җитештерү буенча Татарстан РФ төбәкләре арасында беренче өчлеккә керә; җан башына исәпләгәндә, җитештерү РФ күрсәткечләреннән уртача 1,5 тапкыр артыграк. Индустриаль яктан үсеш алган Татарстанда Т.ф. үзенчәлекләре ш.у. химия, нефть химиясе, машиналар эшләп чыгару, нефть сәнәгатьләренең тупланганлыгы, нык үскән а.х. (терлекчелек комплекслары һәм кошчылык ф-калары, сәнәгатьнең эшкәртү тармаклары һ.б.) б-н бәйле. Аграр-сәнәгать комплексының табигый ландшафтка шундый зур йогынтысы сан.-гигиена халәтен һәм экологияне катлауландыра, җир асты, җир, урман, су һ.б. табигый байлыкларның кимүенә китерә, табигать комплексларының табигый тигезлеген һәм бөтенлеген боза (к. *Әйләнә-тирә мохитнең пычрануы*). Шуңа бәйле рәвештә респ-када Т.ф.ны оптимальләштерү чаралары күрелә: табигый байлыкларны комплекслы һәм тирәнтен эшкәртүне арттыру, икътисадның ресурс сыйдырышлылыгын киметү, чистарту системаларын камилләштерү, икътисади яктан нәтиҗәле һәм экологик хәвефсез технологияләргә күчү. Экологик контроль, бигрәк тә муниципаль, җәмәгатьчелек, прокурор күзәтүләре алып барыла. Әйләнә-тирә мохиткә теге яки бу хуҗалык эшчәнлегенең тискәре йогынтысы ихтималын һәм шуңа бәйле социаль, икътисади һ.б. нәтиҗәләрне булдырмау максатыннан *экологик экспертиза* үткәрелә, шуның нәтиҗәсендә әлеге эшчәнлеккә рөхсәт бирелә, аның экологик таләпләргә туры килүе билгеләнә. ТРда табигый байлыкларны һәм табигатьне рациональ файдалануга караган федераль законнар б-н беррәттән респ-ка законнары да гамәлдә: «Җир асты байлыклары турында» (1992), «Атмосфера һавасын саклау һәм нигезле файдалану турында» (1994), «Җитештерү һәм куллану калдыклары» (1997), «Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» (1999) һ.б. Табигатьне рациональ файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә оештыручы рольне ТРның Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы, ТРның Урман хуҗалыгы министрлыгы, ТРның А.х. һәм азык-төлек министрлыгы, респ-каның башка министрлык һәм ведомстволары, муниципаль оешмалар, ш.у. табигый байлыклар һәм табигатьне саклау буенча федераль терр. органнар уйный.

*Н.Х.Газиев.*

**ТАБИГЫ́Й БАЙЛЫКЛА́Р**, кешеләрнең матди һәм мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен иҗтимагый җитештерү процессында кулланылучы терек һәм терек булмаган табигать объектлары җыелмасы. Табигать күренешләренең теге яки бу классына нисбәте буенча Т.б.ны казылма (литосфера ресурслары), климатик (атм. ресурслары), су (гидросфера ресурслары), туфрак, үсемлек, фауна төркемнәренә аералар. Т.б. тотып бетерелә һәм яңадан булдырылмый торган (файдалы казылмалар), тотып бетерелә ләкин яңадан булдырыла торган (үсемлек һәм фауна), тотып бетерелми торганнарга (атм. байлыклары) бүленә. Т.б.га җир, туфрак, су, җир асты байлыклары, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы, табигый мохитнең рекреацион һ.б. компонентлары керә.

Татарстан терр-ясендә *климат* җылы җәйле (абс. макс. 40 °С) һәм чагыштырмача суык кышлы (абс. миним. –52 °С) уртача-континенталь; темп-ра 0 °С тан югары булган җылы чор — 198–209, салкын чор 156–167 көн дәвам итә. Кояш якынча 2000 сәг. яктырта (апрельдән августка кадәр иң кояшлы чор). Рельеф уртача биеклеге 170 *м* га якын калкулыклы тигезлектән гыйбарәт; миним. абс. билге 53 *м* (1957 елга кадәр 34 *м*), макс. — 381 *м*. Елга үзәннәре респ-ка терр-ясен Кама алдына (Камадан төньякка һәм Иделдән төньяк-көнчыгышка таба), Кама аръягы (Камадан көньякка) һәм Идел алдына (Иделдән көнбатышка) бүлә. Табигый ландшафтларның шактый өлеше табигый-антропоген һәм антропоген урман-кыр һәм кыр (агро-) ландшафтларга әверелгән. *Су ресурслары* җир өсте (*елгалар, күлләр*) һәм җир асты (төче су һәм *минераль сулар*, ш.и. термаль) суларын берләштерә. ТРда җир өсте суларының уртача еллык ресурслары 8,6 *км*$^3$, җирле елга агымының уртача еллык күрсәткече 10 *км*$^3$ тәшкил итә. Төче *җир асты суларының* кулланылучы ресурслары — якынча 3,8 млн. *м*$^3$/*с*. ТР терр-ясендә 3,7 мең агымсу (гомуми озынлыгы 21,7 мең *км*) һәм 8 мең күл (су ресурслары якынча 28 млн. *м*$^3$) билгеләнгән, респ-када су өслегенең гомуми мәйданы 4,4 мең *км*$^2$. 4 зур сусаклагыч — Куйбышев (1955 тән), Түбән Кама (1978 дән), Зәй (1963 тән), Карабаш (1957 дән), 400 дән артык буа бар; 3,7 меңгә якын чишмә һәм гому-

ми мәйданы якынча 30 мең *га* булган 7 меңнән артык *сазлык* исәпкә алынган. Минераль җир асты суларының (шифалы, шифалы-эчәргә яраклы, эчәргә яраклы) кулланылыштагы запаслары тәүлеккә якынча 3,3 мең $м^3$. ТР терр-ясе тайга, яфраклы урманнар һәм урман-дала зоналары тоташкан урында урнашкан. *Үсемлекләр дөньясы* сакланып калган табигый *урман* массивыннан (гомуми мәйданы 1 млн. *га* дан артык), кеше тарафыннан утыртылган утыртмалардан (250 мең *га* га якын), далаланган *болын*, зур сусаклагычлар, вак сулыклар һәм сазлыклардагы су һәм су яны үсемлекләреннән тора. Төньяк районнарда урман-дала зонасының болын-дала фрагментлары б-н караңгы ылыслы-киң яфраклы, нарат һәм вак яфраклы урманнар өстенлек итә; ТР терр-ясенең уртача урманлылыгы 16,9%. Ел саен 3–4 мең *га* урман киселә, 7–8 мең *га* яңадан торгызыла. *Флора* 100 дән артык семьялыкка караган 1330 төр үсемлекне үз эченә ала, алардан 376 төр үсемлек һәм 40 гөмбә ТРның *Кызыл китабына* (2006) кертелгән. ТРның *хайваннар дөньясы* төр һәм бергәлекләрнең байлыгы, экологик-геогр. төркемнәрнең төрлелеге, фаунаның кушылуы б-н сыйфатлана. *Имезүчеләр* — 75 төр, ихтиофауна — 52, *җир-су хайваннары* — 11, *сөйрәлүчеләр* — 8, *кошлар* 295 төрне берләштерә. Умырткалыларның — 136 һәм умырткасызларның 122 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән. ТР терр-ясендә туфракның 10 нан артык тибы: *соры урман туфраклары* (37%), *кара туфраклар* (32%) очрый, кәсле-көлсу, кәсле-карбонатлы, аллювиаль, кара болын туфраклары һ.б. киң таралган. *Файдалы казылмаларның* 70 кә якын төренең тупланышы ачыкланган, шуларның яртысы төп чимал типларының 1100 дән артык чыганагын хасил итә: җылылык-энергетика (*нефть, янучан табигый газлар, казылма күмерләр, янучан сланецлар, торф*), тау-химия (*сапропель, күкерт, фосфоритлар, цеолитлар* һ.б.), тау-техника (*балчык*), минераль-төзелеш (*минераль буяулар, гипс, известьташ* һ.б.); металлар: кара-көрән тимерташ, Mn, Cr; төсле — *бакыр рудалары*, V, Co, Ni, Pb, Ti, Zn; сирәк — Ba, Sr, Ge, Se, Sc, Cd, Li; затлы — *алтын, көмеш*, Pt, Pd, Rh; асылташлар — *алмаз, мәрмәр оникс, малахит*, гранат, аметист, селенит (гипс), чакматашлы үзагач, пирит һ.б.; радиоактив элементлар — уран, торий, газлар ($N_2$, $H_2$, He, $CH_4$, $H_2S$, $CO_2$, Rn); гидроминераль чимал (Br, I, Sr, Li); *шифалы ләмнәр*.

Кешенең тереклек эшчәнлегендә Т.б. билгеле бер роль уйный, аларны куллану барышындагы үзгәрешләр хәзерге һәм киләчәк буын мәнфәгатьләренә турыдан-туры яки читләтеп булса да кагыла. Т.б.дан туктаусыз файдалануның артуы аларны сакчыл һәм хуҗалыкчан куллану зарурлыгын китереп чыгара; икътисадның уңышлы үсеше, табигатьне һәм аның компонентларын саклауда тискәре күренешләрне булдырмый калу шуңа бәйле. Ш.у.к. *Табигатьтән файдалану*.

*Әд.:* Зелёная книга Республики Татарстан. К., 1993; Переведенцев Ю.П., Салахова Р.Х. Введение в геоэкологию атмосферы: Учеб. пособие. К., 2007. *Э.Х.Рәхмәтуллин.*

**ТАБИГЫ́Й КУШЫЛМАЛА́Р**, тере организмнарның яшәү эшчәнлегендәге арадаш яки калдык продуктлар булып торучы һәм бу организмнарның яшәешен тәэмин итүче органик матдәләр. Т.к.ны тикшерү органик химиянең, биохимия, фармакогнозия, фармакологиянең бер өлеше булып тора. Т.к.га, гадәттә, метаболизмның гади продуктларын (метан, серкә к-тасы, этил спирты һ.б.), күмер һәм нефть составына керүче компонентларны; матдәләр алмашы барышында хасил булган ($O_2$, $CO_2$, $H_2O$ һ.б.) яисә терек булмаган табигатьтә очрый торган (минераллар, газлар һ.б.) нәорганик кушылмаларны кертәләр. Югары молекуляр (биополимерлар) һәм түбән молекуляр Т.к. аерып өйрәнелә. Югары молекуляр Т.к.га аксымнар, нуклеин к-талары һәм полисахаридлар, полиизопреноидлар (каучук, гуттаперча), ш.у. катнаш биополимерлар — гликопротеидлар, нуклепротеидлар, липопротеидлар һ.б. керә. Әлеге матдәләр күзәнәкнең төп структур компонентлары булып тора һәм иң мөһим биологик функцияләрне (биол. катализ, нәселдәнлекне саклау һәм тапшыру, матдәләрне күчерү, иммунитет һ.б.) үти. Түбән молекуляр Т.к.га биополимерларны төзүче мономерлар — аминокислоталар, нуклеотид, моносахарид, олигонуклеотид, олигосахарид, липидлар, ш.у. органик кушылмаларның алифатик, алициклик, ароматик, гетероциклик төрләренә караган матдәләр (табигый пигментлар, стероидлар, изопреноидлар, алкалоидлар, флаваноидлар һ.б.) керә. Түбән молекуляр Т.к. организмда биополимерлар синтезы барышында төзелеш материалы ролен үтиләр, биокөйләгечләр (гормоннар, медиаторлар, витаминнар), саклагыч чаралар (токсиннар, антибиотиклар) һәм организмнар арасында химик бәйләгечләр (феромоннар һ.б.) булып торалар. Т.к.ның төп чыганагын үсемлекләр, төрле диңгез организмнары, гөмбәләр һәм микроорганизмнар тәшкил итә. Химик һәм биол. үзлекләренең иң күп төрлелеге б-н изопреноидлар (ш.и. терпеннар) классы аерылып тора. Аларга имезүчеләрнең стероид гормоннары, фитогормоннар, каротиноидлар һәм кайбер витаминнар (А, Д, Е) керә. Терпеннар эфир майларының һәм үсемлек сыгынтыларының төп массасын тәшкил итәләр, ш.у. ылыслы агачларның сагызы б-н бүленеп чыгалар, сәнәгать масштабында техник продуктлар (канифоль, скипидар) эшләп чыгаруда кулланылалар. Т.к.ның зур күпчелеге биол. актив: вирусларга каршы, фунгицид буларак, шешләргә каршы, иммунитет тудыруда, нерв тукымасын кабат торгызуда кулланылалар; фармацевтиканың барлык этапларында төп нигез булып торалар. Алкалоидлар 1 нче буын даруларның (морфин, хинин, кокаин, эфедрин, кофеин һ.б.) нигезен тәшкил итә, стероидлар һәм аларның ярымсинтетик чыгарылмалары 2 нче буын дарулары (эстрогеннар, кортизоннар, карденолидлар һ.б.) барлыкка китерә; табигый һәм ярымсинтетик антибиотикларның — 3 нче буын даруларның төрләре арта бара.

Т.к. бик борынгыдан ук кулланыла башлый (табигый буягычлар, кайбер агулар), 18 йөз ахыры — 19 йөз башына Т.к.ның химик составын өйрәнүгә караган беренче хезмәтләр күренә. Шәраб һәм сөт к-талары (К.В.Шееле, 1769–82), май к-талары, глюкоза, холестерол (М.Э.Шеврель, 1815–25) һ.б. аерып күрсәтелә. Азык продуктлары составына аксымнар, майлар һәм углеводлар керүе ачыклана (Ю.Либих, 19 йөз). Т.к. өлкәсендә Нобель бүләгенә лаек булган галимнәр һәм хезмәтләр: немец галимнәре Э.Фишер (углеводлар һәм ферментлар, 1902), Р.М.Вильштеттер (алкалоидлар, хлорофилл, 1915), Р.Кун (үсемлек пигментлары, 1938), А.Ф.Бутенант (стероид гормоннар, 1939); химик-органиклар П.Каррер (каротиноидлар, витаминнар, 1937), С.Ружичка (терпеннар, 1939). Т.к. химиясе үсешенә Россия галимнәре М.В.Ненцкий, В.С.Гулевич, А.П.Орехов, С.Ю.Юнысов, А.Я.Данилевский, М.М.Шемякин һ.б. зур өлеш кертә.

Татарстанда Т.к.га караган тикшеренүләр 19 йөзнең 2 нче яртысында башлана. Этилен бәйләнеше булган органик кушылмаларның оксидлашу реакциясе ачылу (1888) нәтиҗәсендә терпеннар рәтенең чиксезлеге исбатлана, лимоненның һәм бездә җитештерелә торган скипидарның төп компоненты — α-пиненның төзелеше ачыклана (Е.Е.*Вагнер*), борнеолның камфенга һәм киресенчә төркемләнүе гамәлгә ашырыла (*Вагнер-Мейервейн төркемләнеше*). Ылыслы агачларның сумалалары өйрәнелә, терпеннар классификациясе тәкъдим ителә (1880), моно- һәм биоциклик терпеннарның үзара әверелешләре, пиненның оптик актив лимоненга әверелеше үткәрелә (Ф.М.*Флавицкий*). 20 йөзнең 1 нче яртысында бу өлкәдәге тикшеренүләр дәвам итә: ылыслы агачлардан сагыз агызуның яңа алымы, очучан компонентларны югалтмыйча җыю техникасы эшләнә (А.Е. һәм Б.А.Арбузовлар), абиетин к-тасының структурасы ачыклана, бициклик терпеннарның алифатикларга, аерым алганда, α-пиненның аллоцименга изомерлашуы ачыла (Б.А.*Арбузов*). Скипидардан аерып алынган терпеннарның реакциягә сәләте, әверелү механизмнары, кабат төркемләнүе, стереохимиясе өйрәнелә (З.Г.*Исаева*). 20 йөз ахырында катлаулы чәчәклеләр семьялыгы үләннәренең фитохимиясенә, моно- һәм сесквитерпеннарны модификацияләү, изопреноидларның күкертле биол. актив кушылмаларын синтезлауга караган тикшеренүләр (В.В.*Племенков*) үсеш ала. Изостевиол дитерпиноиды чыгарылмалары рәтендә яңа реакцияләр һәм аның ароматик кушылмаларны сайлап алып бәйләү сәләте ачыла (В.Е.*Катаев*). Үсемлек (амарант, люпин) чыганакларыннан пектиннар һәм аксым алу технологияләре эшләнә, аларның төзелеше, биол. активлыгы, туклыклы азык-төлек һәм терлек азыгы өстәмәләре сыйфатында куллану мөмкинлеге тикшерелә, анемиягә каршы тору сәләтенә ия булган пектин полиметалл комплекслары табыла (А.И.*Коновалов*, В.Ф.*Миронов*). Т.к. өлкәсендәге тикшеренүләр РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында алып барыла.

*Әд.:* В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира. М., 1991; П л е м е н к о в В.В. Введение в химию природных соединений. К., 2001; Comprehensive Natural Products Chemistry. N.Y.-L.-Tokio, 1998–99. V. 1–8. *В.В.Племенков.*

**ТАБИГЫ́Й ТЕРРИТОРИА́ЛЬ КО́МПЛЕКС**, үзара катлаулы һәм тыгыз бәйләнештәге һәм төрле дәрәҗәдә (геогр. тышчадан фациягә кадәр) бербөтен система булып оешкан табигать компонентларының пространствода закончалыклы берләшүе; физик географиянең төп төшенчәләреннән берсе. Гадәттә, җир кабыгы участогын, аңа бәйләнешле рельефны, җир асты һәм җир өсте суларын, җир өслегенә якын атмосфера катламын, туфрак, үсемлекләр, хайваннар дөньясын үз эченә ала. Аерым Т.т.к. һәм аларның компонентлары арасында матдәләр һәм энергия алмашу бара. Татарстанда Т.т.к. Идел-Кама саклаулыгында һәм Түбән Кама милли паркында фация (һәм аймаклар) дәрәҗәсендә өйрәнелә.

**ТАБИГЫЯТЬЧЕЛӘ́Р ҖӘМГЫЯТЕ́**, фәнни җәмгыять. 1869 елның 12 маенда Казан ун-ты каршында 1 нче Бөтенроссия табигыятьчеләр җыены карары нигезендә төзелә (карарда Россиянең билгеле бер төбәген («полосасын»), бигрәк тә геологиясен, ботаника һәм зоологиясен өйрәнүгә юнәлтү максатында җирле фәнни көчләрне үстерү һәм берләштерү кирәклеге күрсәтелә). Тикшеренүләр өлкәсе — Россиянең Идел елгасыннан Көнчыгышка таба, фактта — «Польша патшалыгыннан — Бөек Пётр култыгына, Яңа Җирдән Босфор бугазына һәм Каспий арьягы өлкәсенә кадәр» диелә. Җәмгыятьнең беренче җитәкчеләре: зоология проф. Н.П.*Вагнер* (президенты), физика проф. И.А.*Больцани* (вице-президент), зоолог һәм зоогеограф М.Н.*Богданов* (секретарь һәм казначы). Төрле елларда Т.җ.нең президенты вазифасын А.А.*Штукенберг*, Б.К.*Поленов*, А.А.*Остроумов*, А.Я.*Гордягин*, Н.А.*Ливанов* үти. Җәмгыять әгъзалары 3 категориягә бүленә: хакыйкый әгъза (взнос түлиләр), әгъза-хезмәткәр (взнос түләмиләр) һәм шәрәфле әгъзалар («җәмгыять эшенә үзләренең шәхси мөнәсәбәте б-н ярдәм итүчеләр һәм ... аңа сизелерлек файда китерүчеләр»). Җәмгыять эшчәнлегенең төп көчләре — аның хакыйкый әгъзалары (560 тан артык кеше): табибләр, урман белгечләре, агрономнар, хәрбиләр, гимназия укытучылары, Казан ун-ты студентлары һәм профессорлары, ш.и. Н.-Б.З.*Векслин*, К.В.*Ворошилов*, Н.А.*Головкинский*, Д.И.*Дубяго*, Г.Х.*Камай*, Н.О.*Ковалевский*, Н.М.*Любимов*, академиклар А.Е.*Арбузов*, И.А.*Тарчевский*, И.В.*Тюрин* була. Әгъза-хезмәткәрләр (96 кеше) арасында танылган ботаниклар В.И.Талиев, И.И.Спрыгин, П.Н.*Крылов*, мәгърифәтче һәм җәмәгать эшлеклесе И.В.*Терегулов*, футурист шагыйрь В.В.Хлебников һ.б. бар. Шәрәфле әгъзалар (94 кеше) булып ботаник А.Н.Бекетов, ихтиолог һәм географ Л.С.Берг, психиатр В.М.*Бехтерев*, химиклар А.М.*Бутлеров*, Д.И.*Менделеев*, табигыятьче академик В.И.Вернадский, патолог Р.Вирхов, климатолог А.И.Воейков, эволюционистлар Ч.Дарвин, А.Н.Северцов, палеонтолог А.А.Иностранцев, генетик Н.К.Кольцов, инглиз геологы Р.Лайелл, орнитолог М.А.Мензбир, селекционер-бакчачы И.В.Мичурин, сәяхәтче Г.Н.Потанин, агрохимик Д.Н.Прянишников, физиолог И.М.Сеченов, астроном О.В.Струве, графиня П.С.Уварова (Мәскәү археол. җәмгыяте рәисе), Арктиканы өйрәнүче О.Ю.Шмидт һ.б. тора. Җәмгыятьнең беренче 25 еллык эше дәверендә 305 утырыш үткәрелә, 445 фәнни чыгыш ясала, 151 экспедиция оештырыла (Т.җ. эшчәнлеге 1869–1916 еллар эчендәге утырыш беркетмәләрендә чагыла). Т.җ. катлаулы сугыш еллары шартларында да (1905–06, 1917–21, 1941–45) үз эшен дәвам иттерә. Фәнни һәм гамәли эшен ул халык арасында табигать фәннәре буенча лекцияләр оештыру б-н бергә алып бара. 1871–1965 елларда «Труды общества естествоиспытателей при Казанском университете» басмасы чыгарыла. Җәмгыять әгъзалары Казан фәнни-сәнәгый күргәзмәсен үткәрүдә (1890), Казанда зоопарк төзүдә (1890–91), Куйбышев сусаклагычын төзү б-н бәйле (1939) һәм оборонага караган (1940 еллар) мәсьәләләрне хәл итүдә; СССР ФА Биол. бүлеге каршындагы азык-төлек һәм терлек азыгы ресурсларын арттыру комиссиясе эшендә (1941–45), Бөтенроссия табигатьне саклау җәмгыятенең Татарстан бүлеге эшчәнлеген яңадан торгызуда (1947) катнашалар. Идел-Кама тыюлыгының 1918–20 елларда проф. Н.А.Ливанов җитәкчелегендә Раифа урманы фаунасында тикшеренүләр башланган аеруча саклаулы терр-яләрне аерып алу мәсьәләләрен хәл итү Т.җ.нең зур казанышы санала. Т.җ.нең соңгы утырышлары 1967 елда уза.

*Әд.:* Обзор деятельности Общества естествоиспытателей при Императорском Казанском университете за первое двадцатипятилетие его существования. 1869–1894. К., 1894; К о л е с н и к о в А.Н. Первые годы Казанского общества естествоиспытателей // Уч. зап. Казан. ун-та. 1955. Т. 115, кн. 8; Очерки истории Казанского университета. К., 2002. *В.И.Гаранин.*

**ТАБИ́ЕВ** Бәхтияр Хәсән улы (14.5.1940, Голҗа ш., Кытай — 27.9.1999, Алма-Ата ш., Казакъстан Респ-касы), нәкышьче, Казакъстан ССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1988). Пенза губернасыннан чыккан татар морзалары Табиевлар нәселеннән. 1955 елда Табиевлар гаиләсе СССРга күченеп килә. Фрунзе сәнгать уч-щесен (1960), В.И.Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тын (акад. А.М.Грицай остаханәсе, 1967) тәмамлый. 1967–72 дә Алма-Ата сәнгать уч-щесендә укыта. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1970), Казакъстандагы Татар мәдәни үзәкләре ассоциациясе президенты (1990), Париждагы Халыкара сәнгать үзәге (1998) президенты. СССР СА дипломанты (1991, «Арал һәм Арал буе» әсәрләре циклы). Нәкышьтә үзенчәлекле иҗади юнәлеш тудырган «алтмышынчылар» буыны осталарының берсе. Иҗатында символик-фәлсәфи һәм лирик яңгыраш алган күчмә төрки дала образы Т.ның жанрлы картиналарында төп урынны били. Нәкышьченең картиналары фикер бөтенлеге, төсләр палитрасының сыгылмалылыгы һәм форма гомумилеге б-н аерылып тора. Т. әсәрләрен натурадан төшерелгән этюдлар, карандаш б-н ясалган рәсемнәр күплеге нигезендә иҗат итә. Казакъ авылының көндәлек тормышын, кешеләрен, чабаннар хезмәтен шигъри төсләрдә чагылдырган «Угыллар» (1968), «Базар», «Кечкенә ишегалды» (икесе дә — 1970), «Бәрәнләү» (1973), «Сарык утарында» (1976), «Борынгы авыл» (1980) кебек әүвәлге хезмәтләрендә үк яшәешнең тирәнтен этник башлангычларын ачарга омтылуы күренә. «Очрашу» (1985), «Җилле көн», «Кич» (икесе дә — 1986), «Тирмәдә» (1994–95), «Голҗа базары» (1996), «Кавын тоткан малай» (1998–99) кебек соңрак чор әсәрләренә чынбарлыкны метафорик һәм экспрессив («Арал һәм Арал буе», «Арал балалары» картиналары сериясе, 1990–96) кабул итү хас.

Респ-ка — «Казакъстан рәссамнары» (Мәскәү, 1976, 1987), «Җиңүнең 40 еллыгы» (Алма-Ата, 1985) һ.б.; бөтенсоюз — «Октябрь юбилеена» (Мәскәү, 1961), «Җир һәм кешеләр» (Мәскәү, 1979), «СССР — Туган илебез» (Мәскәү, 1982), «Бөек Октябрьнең 70 еллыгы» (Мәскәү, 1987), «Нәкышь-1989» (Мәскәү, диплом б-н бүләкләнә) күргәзмә-конкурсында һ.б.; Париждагы Халыкара сәнгать үзәге күргәзмәсендә (1998); бөтента-



Б.Х. Т а б и е в. «Очрашу». 1985. Казакъстанның А. Кастиев исем. Дәүләт сәнгать музее.



Б.Х. Т а б и е в. «Тозлы җил». 1996. Дәүләт Третьяков галереясы.

тар — «Татарт» (С.-Петербург–Казан, 1991); ТР Рәссамнар берлеге (Мәскәү–Казан, 2007) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Әнкарада (1992, З.Тусипова б-н берлектә), Алма-Атада (2000), Казанда (2003) уздырыла.

Әсәрләре Дәүләт Третьяков галереясында, Көнчыгыш халыклары Дәүләт сәнгать музеенда (Мәскәү), А.Кастиев исем. Казакъстан Дәүләт сәнгать музеенда (Алма-Ата), Кыргыз Респ-касы Дәүләт сәнгать музеенда (Бишкәк), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Франция, ГФР, АКШ, Австрия, Төркиядәге шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Арсеньева Ю. Постигая современность // Творчество. 1977. № 7; Какимжанова А. Художник Б.Табиев // Искусство. 1984. № 4; Бахтияр Табиев. Алматы, 2000.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ТАБИ́ЕВ** Фикрәт Әхмәтҗан улы (4.3.1928, Рязань өлкәсенең Ермишь р-ны Әҗи а. — 3.6.2015, Мәскәү), партия һәм дәүләт эшлеклесе, дипломат, икътисад фән. канд. (1955). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1951), шунда ук политэкономия кафедрасында эшли. 1957–59 елларда КПССның Татарстан өлкә ком-тында фән, мәктәпләр һәм мәдәният бүлеге мөдире, идеология буенча секретарь, 2 нче секретарь (1959 дан), 1 нче секретарь (1960 тан). 1979–86 да Әфганстан Демократик Респ-касында СССРның Гадәттән тыш һәм Вәкаләтле илчесе. 1986–90 да РСФСР МС рәисенең 1 нче урынбасары, 1992–93 тә РСФСР ЮС каршындагы Федераль милек фонды рәисе. 1995 тән «Нефтек» холдинг компаниясенең баш киңәшчесе (Мәскәү).

Т. КПССның Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре вазифасын башкарган еллар (1960–70 еллар) Татарстанның социаль-икътисади тормышында зур үзгәрешләр барган, Татарстан а.х. үсеш алган, заманча сәнәгый-индустриаль респ-кага әверелгән вакытка туры килә. Бу дәвердә Казан органик синтез з-ды, илдә нефть химиясе сәнәгате өлкәсендә иң зур пр-тиеләрнең берсе — «Түбәнкаманефтехим», Түбән Кама шин з-ды, КамАЗ пр-тиеләре комплексы, Икътисади ярдәмләшү советының Европа илләренә чыккан, 5 мең *км* дан артыкка сузылган, халыкара «Дуслык» халыкара магистраль нефтьүткәргече, Түбән Кама ГЭСы, Зәй ГРЭСы кебек сәнәгый җитештерү гигантлары төзелә. Машиналар, самолётлар, судноляр, приборлар төзелеше җитди үсеш ала. Заманча алга киткән инфраструктуралы Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Зәй, Җәлил шәһәрләре үсә.

Икътисади потенциалы ягыннан ТАССР кайбер союздаш респ-калардан (Молдавия ССРдан, Балтыйк буе респ-каларыннан һ.б.) күпкә алга китә. Татарстанда авыл торак пунктларын электрлаштыру, радиолаштыру һәм кинофикацияләштерү эшләре тәмамланып килә, авыл районнарын газлаштыру буенча зур эш башкарыла. 1970 тә ТАССРда еллык нефть чыгару күләме 100 млн. *т* була (илдә иң югары күрсәткеч, 1976 га кадәр саклана). Казанда яңа микрорайоннар төзелә, торак төзелеше үсеш ала, респ-каның кайбер районнарында үрнәк авыл торак пунктлары барлыкка килә: Биектау р-нында Шәпше авылы, Актаныш район үзәге һ.б. Югары мәктәп, мәдәният, сәнгать, спорт тиз үсә. Н.К.Крупская исем. Ленинград мәдәният ин-тының (1969), Волгоград физкультура һәм спорт ин-тының (1975) һәм Мәскәү энергетика ин-тының (1976) Казан ф-ллары ачыла, Казан ун-тының, Казан авиация, химия-технол. һәм вет. ин-тларының яңа корпуслары төзелә. Казанда Спорт сарае (1966), архит-расы һәм инженерлык чишелеше буенча уникаль цирк бинасы (1967), Химиклар мәдәният сарае (1968), Төзүчеләр мәдәният сарае (1972), Түбән Камада Нефтехимиклар мәдәният сарае (1966) һ.б. файдалануга тапшырыла. Шуның б-н бергә 1960–70 елларда милли мәктәпләрдә татар балаларын укытуга, халыкның көндәлек тормышында татар телен куллануга игътибар кими. Икътисад һәм мәдәният үсешендәге югары казанышлары өчен Татарстан АССР Октябрь революциясе (1970) һәм Халыклар дуслыгы (1972) орденнары, берничә тапкыр КПСС ҮК, СССР МС һәм ВЦСПС күчмә Кызыл байраклары б-н бүләкләнә.



Ф.Ә.Табиев.

1979 ның декабрендә Т. СССРның Әфганстандагы Гадәттән тыш һәм Вәкаләтле илчесе итеп раслана. Ул дәвердә Әфганстанда идарә иткән Халык-демократик партиясе фракцияләренең йогынтылы лидерлары Хафизулла Әмин, Бабрак Кармаль һәм Нәҗибулла җитәкләгән эчке көчләр арасында хакимият өчен көрәш бара. Т. ил җитәкчелеген Әфганстандагы сәяси, хәрби һәм икътисади вазгыять турында төгәл һәм объектив мәгълүмат б-н тәэмин итә, әлеге дәүләтнең эчке тормышы һәм тышкы сәясәте тотрыклылыгын тәэмин итү өчен кертелгән совет гаскәрләренең чикләнгән контингенты җитәкчелеге б-н эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыра, бер үк вакытта дәүләтара мөнәсәбәтләрне җайлауның катлаулы мәсьәләләрен хәл итә; 1981 нең 10 декабрендә Мәскәүдә дуслык һәм үзара ярдәмләшү турында ике яклы совет-әфган килешүенә кул куела. 1986 ның июлендә Т. РСФСР МС Рәисенең 1 нче урынбасары итеп билгеләнә; вазифасына туры китереп, аңа РСФСРда финанс-икътисад блогы һәм сәнәгый җитештерү, милли мөнәсәбәтләр өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү җаваплылыгы йөкләнә. Т.ның әлеге эшчәнлек дәвере ил тормышының социаль-икътисади нигезләрен тамырдан үзгәртеп кору вакытына туры килә.

Татарстан икътисады үсеше мәсьәләләренә, партиянең халык хуҗалыгы б-н идарә итү алымнарына, ил икътисадын камилләштерү һ.б. мәсьәләләргә багышланган хезмәтләр һәм басмалар авторы. 1959–80 дә ТАССР ЮС, 1962–79 да СССР ЮС депутаты, 1986–90 да СССР ЮС Президиумы әгъзасы, 1989–91 дә СССР халык депутаты. 1961–90 да КПСС ҮК әгъзасы. Биш Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Халыклар дуслыгы, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, кайбер чит илләр орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казан (2008), Чаллы (2008) шәһәрләренең мактаулы гражданы.

Х е з м.: Экономика: творчество плюс организация. М., 1967; Кладовая резервов. М., 1971; Экономика Татарии: Итоги и перспективы. К., 1972; Совершенствование форм и методов партийного руководства хозяйством в условиях развитого социализма. К., 1973; Проблемы экономики сельского хозяйства Татарии. К., 1975.


*Әд.:* Шафиков Я. Фикрят Табеев. К., 2001; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3; Фикрят Табеев. Судьбе благодаря и вопреки. К., 2013.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**ТАБИ́ЕВА** Динә Мөхәммәт кызы (2.10.1929, Казан), невропатолог, мед. фән. д-ры (1981), проф. (1982), ТАССРның атказ. табибе (1980). Ф.Ә.*Табиевның* хатыны. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), Казандагы дәвалау учреждениеләрендә табиб-терапевт булып эшли. 1960 елдан Казан ГИДУВының нерв авырулары кафедрасында, рефлексотерапия кафедрасын оештыручы һәм аның мөдире (1977 дән); СССРда беренче булып (1978), Т. башлангычында кафедра каршында рефлексотерапия стационары ачыла. 1982 дән Мәскәүдә: В.П.Сербский исем. Социаль һәм мәхкәмә психиатриясе федераль дәүләт учреждениесе дәүләт фәнни үзәгенең рефлексотерапия бүлеге мөдире; 1991 дән мәхкәмә экспертизалары бүлегендә әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. 1976 да — Японидә, 1983 тә — Кытайда, 1995 тә Вьетнамда фәнни командировкаларда була. Хезмәтләре инә рефлексотерапиясенә (ИРТ) карый. Т. нерв системасы авырулары вакытындагы клиник-электрофизиологик бәйләнешләрнең кайбер аспектларын ачыклый; неврология һәм психиатриядә ИРТ куллануның методологик принципларын; алкоголизм очрагында ИРТның вегетатив тайпылышларга тәэсирен өйрәнә; төрле неврозлардан дәвалаганда дарусыз дәвалау ысулларын һәм дару матдәләрен комплекслы куллануны гамәлгә кертә һ.б. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Россия рефлексотерапевтлар ассоциациясе вице-президенты (2006 дан). СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә. Казан мед. академиясенең мактаулы профессоры (2005 тән).

Х е з м.: Ухоиглотерапия. К., 1976 (автордаш); Атлас иглорефлексотерапии. К., 1979; Иглотерапия. М., 1994; Практическая акупунктура. Смоленск, 1997; Руководство по иглорефлексотерапии. М., 2006; Иглотерапия: Интегративный подход. М., 2010.

**ТАБЫЛДИ́ЕВ** Габбас (19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөзнең 1 нче яртысы), график. «*Ак юл*» татар балалар ж-лында басылган рәсемнәр авторы (1913–16). Татар гаиләсенең өйдәге шөгыльләрен чагылдырган, гади авыл интерьерын җентекләп күрсәткән «Һәркем үз эше белән мәшгуль» рәсеме б-н танылa (1913).



Г. Т а б ы л д и е в. «Һәркем үз эше белән мәшгуль». «Ак юл» журналындагы рәсем. 1913.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Искусство Татарии: История изобразительного искусства и архитектуры с древнейших времён до 1917 года. М., 1987.

**ТАБЫШМА́К**, татар фольклорының афористик жанры. Берәр әйбернең яисә күренешнең киная б-н сурәтләп әйтелгән мәгънәсен тиз табу сорала. Т.ларның барлыкка килү вакыты турында ышанычлы мәгълүмат юк. Т.ның бик борынгы фольклор жанрларыннан булуы ихтимал. Т.ның барлыкка килүе хайваннар кешеләр телен аңлыйлар дигән ышануга нигезләнгән, тегеләр яки бу сүзләрне әйтүне тыю (табу) б-н бәйле. Табулаштырылган сүзләр табышмакта башка сүзләр б-н алыштырылган (поши — «мөгезбай», куян — «озын колак», аю — «камыт аяк»).

Татар Т.ларын: 1)чагыштыруга нигезләнгән; 2)метонимиягә нигезләнгән; 3)аваз ияртемнәренә нигезләнгән; 4)арифметик төрләргә бүлеп карыйлар. 1 нче төркем табышмакларда бер күренеш яисә предмет икенчесе б-н чагыштырыла (тавис кошы турында: «Үзе яшел чирәмдәй, койрыгы чиккән келәмдәй, чук-чуклы калфак кигән, безгә ерактан килгән»). 2 нче төркем Т.ларда предмет атамалары алар б-н эчке бәйләнеше булган сүзләр б-н алыштырыла (чабата турында: «Бер тычканга ике койрык»). 3 нче төркем Т.ларда аваз ияртемнәре кулланыла («Зыр-зыр түки, Зырмадай түки, Әләшки, пешки түки, Әләлеки түтеки»; җавабы: тегермән тарту, иләктән иләү, бәлеш пешерү, ашау процессы). Арифметик Т.лар, кагыйдә буларак, күләмле һәм мәзәкчән («Агачка унике карга кунган. Аучы килеп икесен аткан. Агачта ничә карга калган?»; җавабы: берәү дә калмый, — икесе егылып төшә, калганнары очып китә).

Татар Т.ларындагы популяр образлар: кояш һ.б. күк җисемнәре, явым-төшемнәр, үсемлекләр һәм хайваннар образлары. Татар мифологиясе персонажлары — Алып, Аждаһа, Дию һ.б. да бар. Вакытлар үтү б-н, жанрның функцияләре һәм куллану даирәсе үзгәрә: Т. күңел ачу һәм тәрбия өлкәсенә, балалар фольклорына күчә. Татар Т.ларын Н.Исәнбәт, Х.Мәхмүтов өйрәнәләр.

*Әд.:* Татар халык табышмаклары. К., 1970; Татар халык иҗаты: Табышмаклар. К., 1977; М ә х м ү т о в Х.Ш. Кечкенә дә төш кенә: Табышмакларның жанр үзенчәлекләре. К., 1980; Афористические жанры татарского фольклора: Дис. ... К., 1995.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ТА́ВЛИН** Гурий Иванович (25.12.1925, Зәй р-ны Урта Баграж а. — 17.2.1998, Казан), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1996). 1946 елда Казан пед. ин-тына укырга керә. 1950 дә, «советларга каршы пропаганда алып барганы өчен», 10 елга ирегеннән мәхрүм ителә; 1954 тә азат ителә һәм аклана. 1955 тә Казан пед. ин-тын тәмамлый, район һәм респ-ка газеталары редакцияләрендә, Татарстан китап нәшриятында, Казан хроникаль-документаль фильмнар студиясендә эшли. 1972–92 дә Казан һәм Яшел Үзән урта мәктәпләрендә укыта. Әсәрләре вакытлы матбугат битләрендә 1950 еллар ахырында басыла башлый. «Сары яфраклар коела» (1960), «Тәвәккәл таш яра» (1962), «Йолдызлар безгә янәшә» (1970) һ.б. новеллалар җыентыклары авторы. Т.га Сталин чоры репрессияләрен чагылдырган «Афәт» (1990–91) трилогиясе танылу китерә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз, Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х у җ и н М. Сары яфраклар коелганда // Казан утлары. 2005. № 12.

**ТАВЫ́К ҮЛӘНЕ́** (Caltha), казаякчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 90 га якын төре билгеле, Евразиядә, Төньяк Америка, Австралиядә таралган. ТР терр-ясендә бер төре — гади Т.ү. (саз төнбоегы) (C. palustris) бар. Республиканың барлык районнарында очрый. Сазлыкларда, яр буйларында, сазлыклы болыннарда үсә. 15–50 *см* биеклектәге үсемлек. Тамыры җепсыман. Сабагы ботаклы, күтәренке. Яфраклары куе яшел, ялтыравыклы, йөрәксыман, түбәнгеләре — саплы, өскеләре — утырма. Чәчәкләре эре, алтынсу-сары төстә. Җимеше — бик күп ялтыравыклы кара орлыклы эре табакча. Апрель–майда чәчәк ата. Җимешләре



Гади тавык үләне (саз төнбоегы).

июнь–июльдә өлгерә. Җир өсте өлешләрендә алкалоид, гликозид, каротин, С витамины бар. Халык медицинасында яфракларыннан ясалган төнәтмәне матдәләр алмашы бозылганда, золотуха (төче авыруы) вакытында, яфрак һәм чәчәк бөреләрен яра төзәтү чарасы буларак кулланалар. Җиңелчә агулы үсемлек; мөгезле эре терлек агуланырга мөмкин. Гади Т.ү.нең катмарлы чәчәкле культуралы сортларын декоратив үсемлек буларак үстерәләр. Баллы.

*Әд.:* Б а к и н О.В., Р о г о в а Т.В., С и т н и к о в А.П. Сосудистые растения Татарстана. К., 2000.

**ТАВЫ́К ЧӘЧӘГЕ́** (Parnassia), тавык чәчәгечәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Төньяк ярымшарның уртача һәм субтропик поясларында 55 төре билгеле. Саз Т.ч. (P. palustris) респ-каның барлык районнарында очрый. Дымлы һәм сазлыклы болыннарда, елга, инеш, чишмә буйларында үсә. 15–30 *см* биеклектәге үсемлек. Тамыры кыска, чук. Сабагы кырлы. Тамыр яны яфраклары таралгыда, сабак яфрагы бер, утырма, сабакны чорнап алган. Чәчәкләре берле, ак төстә, сабак очында урнашкан. Җимеше — күп орлыклы бер оялы ачылучан тартмачык. Июль–августта чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Баллы, агулы үсемлек. Җир өсте өлешләрендә сапониннар, дуплау матдәләре, алкалоидлар бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе тынычландыру, кан туктату, бөрештергеч һәм үт кудыру чарасы буларак кулланыла. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**«ТАВЫ́Ш»**, атналык иҗтимагый-сәяси газета. Социалист-революционерлар партиясенең татар ком-ты органы. 1907 елның 23 апреленнән августына кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә, барысы 6 саны чыга. «*Таң йолдызы*», «Таң мәҗмугасы» г-таларының дәвамчысы. Нашире һәм мөхәррире — М.Биккинин, 18 майдан — Х.Әбүзәров, фактик мөхәррире — Г.*Исхакый*. Актив авторлары арасында — Г.Кариев, С.Рәмиев, Г.Тукай, Ф.Туктаров. Чит илләр һәм гомумроссия хәбәрләре, җирле яңалыклар басыла, сәяси тематикага, татар теле һәм әдәбияты, мәгариф, театр мәсьәләләренә игътибар бирелә. «Татар газеталары» сәхифәсендә гомумән вакытлы матбугатка да, «Йолдыз», «Вакыт», «Борһане тәрәккый», «Дума» һ.б. газеталардагы аерым мәкаләләргә дә бәя бирелә. Июнь саны чыкканнан соң, редакциядә тентү уздырыла, тыелган басмалар табыла. Шуның б-н бәйле рәвештә газета ябыла.

**ТАГА́Й** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 21 *км* көнбатыштарак, Юраш елгасы (Туйманың уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 86 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 1680 нән Тагай Пүчинкәсе буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Илга Юграж исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, су тегермәне эшли. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 1084,5 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Грахово волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1859 да — 285, 1887 дә — 510, 1905 тә — 616, 1920 дә — 633, 1926 да — 656, 1938 дә — 517, 1949 да — 382, 1958 дә — 271, 1970 тә — 196, 1979 да — 150, 1989 да — 111, 2002 дә — 86 кеше.

**ТАГА́Й БӘК** (? – 1369 елдан соң), Алтын Урда бәге. Бәлҗәмин шәһәре аксөякләреннән; Бәлҗәмин идарәчесе булуы ихтимал. 1361 елда, Алтын Урдада үзәк хакимият көчсезлән-

гән дәвердә, Мухша Олысын яулап ала. 1368 гә кадәр анда үз исеменнән акча суктыра. 1365 тә Рязань кенәзлегенә һөҗүм итә, Переяславль шәһәрен басып ала һәм яндыра; кайтканда, кенәз Олег Рязанский тарафыннан тар-мар ителә. Фаразланганча, 1367–68 еллар тирәсендә Мухша Олысын Мамай әмир буйсындыра. Т.б.нең аннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Фёдоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973. *И.Л.Измайлов.*

**ТАГАШУ́Р** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 20 *км* төньяктарак, Көшкәт елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 132 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1768 дән соң нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1880 еллар уртасындагы көчле янгыннан соң, халкы күпләп күрше торак пунктларга күченә. 1908 дә Т.да чиркәү-приход мәктәбе ачыла. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 734,6 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Чепья волостенда, 1921 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1795 тә — 25, 1811 дә — 74 ир-ат; 1897 дә — 71, 1905 тә — 256, 1920 дә — 333, 1926 да — 266, 1938 дә — 340, 1949 да — 142, 1958 дә — 147, 1970 тә — 156, 1979 да — 141, 1989 да — 122, 2002 дә — 129 кеше.

**ТАЖУРИ́ЗИНА** Зөлфия Абделхак кызы (26.6.1932, Түбән Новгород өлкәсенең Сафаҗай а.), философ, филос. фән. д-ры (1992), проф. (1993), Мәскәү ун-тының атказ. профессоры (2005). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1955), Таулы Алтай пед. ин-тында эшли. 1958 елдан Эстәрлетамак урта мәктәбенең тарих укытучысы (БАССР). 1965 тән Мәскәү ун-тының дини фәлсәфә һәм дин белеме кафедрасында. Хезмәтләре җәмгыятьнең рухи тормышына, тарихка, атеизм эволюциясенә карый.

Х е з м.: Буржуазный атеизм в прошлом и настоящем. М., 1976; Исследование проблем истории атеизма за десять лет в СССР (1967–1977) // Вестн. Моск. ун-та. Сер. 7. Философия. 1977. № 6; Актуальные вопросы истории атеизма. М., 1979; Идеи свободомыслия в истории культуры. М., 1987.

**ТАЖДА́РОВА** (псевд., чын фамилиясе Әхмәдуллина) Нәгыймә Әхмәдулла кызы (25.5.1888, Казан губ., Казан өязе Кече Аты а., хәзер Арча р-ны Утар-Аты а. — 16.3.1947, Казан), драма актрисасы, ТАССРның халык (1939), РСФСРның атказ. (1940) артисты. Г.*Кариев* шәкерте. Сәхнә эшчәнлеген 1915 елда «Сәйяр» труппасында башлап җибәрә, Рокыя, Зәйнәп («Тигезсезләр», «Яшьләр», Ф.Әмирхан), Салиха («Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!», С.Рәмиев), Елена («Ванюшин балалары», С.А.Найдёнов), Полина («Мещаннар», М.Горький) кебек зур рольләр башкара. Актриса Галиябану (шул исем. әсәр буенча, М.Фәйзи) ролендә, тормыш шартлары йогынтысында тыныч һәм хәйләсез кызда тәвәккәллек һәм рухи ныклык кебек сыйфатлар барлыкка килүен яктыртып, характерның күпкырлылыгын гәүдәләндерә. 1917–19 да — Оренбург шәһәрендәге «Ширкәт» труппасында, 1919–20 дә — Бозаулык шәһәрендәге фронт театрында, Кызыл Армия агитпоездларындагы һәм Төркестан фронты частьларындагы театр бригадаларында уйный. 1920 дә Ташкент татар театрында, 1921 дә Казанда 1 нче үрнәк татар театры составында, 1922–26 да Уфада Татар-башкорт театрында, 1926 дан Татар акад. театрында. Т.ның бу чордагы рольләре арасында рев-ция идеяләренә тугры разведчик кыз Сәгыйдә («Күмелгән кораллар», Һ.Такташ), Айсылу («Наёмщик», Т.Гыйззәт), Татьяна («Разлом», Б.А.Лавренёв), Оксана («Эскадра һәлакәте», А.Е.Корнейчук) һ.б. була. Әлеге образлар аркылы актриса характерларның психол. тирәнлеген үсештә гәүдәләндерә. Т. башкаруында йомшак холыклы, зыялы Татьяна рев-ция куйган максатларга ирешүдә газаплы авыр юл үтә; комиссар Оксана образы нык ихтыяр көче, көчле дисциплина, кырыслык б-н сугарылган. Гөлниса («Ташкыннар», Т.Гыйззәт) ролендә Т. җәберләнгән хатын-кыз язмышын тормышчан итеп гәүдәләндерә. Актриса, әлеге образга индивидуаль якын килеп, аны төгәл, һәркемгә таныш сыйфатлар б-н тулыландырып, аңа гомуми мәгънә сала. Т. ш.у. Һаҗәр («Ямьсез тормыш», Ф.Сәйфи-Казанлы), Җәмилә («Бәхетсез егет», Г.Камал), Ләйлә («Миркәй белән Айсылу», Н.Исәнбәт), Фатыйма («Тукай», Ә.Фәйзи), Сажидә («Шәмсекамәр», М.Әблиев), Хөбәйбә («Мактаулы заман», Т.Гыйззәт), Марья Антоновна («Ревизор», Н.В.Гоголь), Аксинья, Юлия («Урман», «Төшемле урын», А.Н.Островский), Амалия («Юлбасарлар», Ф.Шиллер) рольләрен дә уңышлы башкара.



Н.Ә.Таждарова.



Н.Ә.Таждарова Нәгыймә ролендә («Яшь гомер», Г.Коләхмәтов).

*Әд.:* Иляловa И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; Еники А. Н.Таждарова. К., 1957. *И.И.Илялова.*

**ТАҖЕТДИ́Н** Тәлгать Сафа улы (12.10.1948, Казан), дин һәм җәмәгать эшлеклесе. «Мир Араб» мәдрәсәсен (Бохара ш., 1973), «әл-Әзһәр» ислам ун-тын (Каһирә ш., 1978) тәмамлый. 1978–1980 елларда — Мәрҗани мәчете имам-хатибы (Казан ш.). 1980 нән СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәте рәисе һәм мөфти. Бер үк вакытта, 1990 нан, Мөселман оешмаларының тышкы элемтәләр ассоциациясе рәисе, «шәех әл-ислам» – ислам дине башлыгы дәрәҗәсенә лаек була. СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәте *Россия һәм БДБның Европа илләре мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте* итеп үзгәртелгәннән соң (1994), Т. югары мөфти булып сайлана. РФ Президенты каршындагы дини берләшмәләр б-н үзара бәйләнешләр Советы (1995 тән), Россия Динара совет Президиумы әгъзасы (1998 дән). РФ мөселманнарының ЮНЕСКО, «Ислам конференциясе» оешмаларының, мөселманнарның Европа лигасындагы рәсми вәкиле буларак, Т. РФ мөселманнарын башка илләрдәге мөселманнар б-н якынайтуга йогынты ясый, РФдә диннәр һәм милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрне яхшыртуга, ислам дөньясында Россиянең уңай образы формалашуга ярдәм итә. Почёт, Дуслык, Рус православие чиркәвенең Мәскәү кенәзе Изге Даниил орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Силантьев Р.А. Ислам в современной России: Энцикл. М., 2008.

**ТАҖЕТДИ́Н бине́ ГАБДЕРРӘШИ́Т ИШТИРӘКИ́** (5.1.1768, Самара губ., Бөгелмә өязе Түбән Иштирәк а. — 12.4.1841, Вятка губ., Малмыж өязе Түбән Сасна а.), дин эшлеклесе, шагыйрь, хаттат. Түбән Иштирәк авылы мәчетендә мулла, 1794 елның сентябреннән Түбән Сасна авылы мәдрәсәсендә имам һәм мөдәррис. Берничә, ш.и. Ә.Курсавиның рациональ карашларына каршы булган кульязма трактатлар авторы. Р.Фәхретдин сүзләренә караганда, төрле авторларның 40 тан артык китабын күчереп язган. Р.Фәхретдиннең «Асар» (Оренбург, 1904) хезмәтенә кертелгән шигъри формадагы ике хаты сакланган.

*Әд.:* Фәхретдин Р. Асар. К., 2006. *А.М.Ахунов.*

**ТАҖЕТДИ́Н бине́ ЮНЫ́С әл-БОЛГАРИ́** (12 йөзнең 2 нче яртысы — 13 йөзнең 1 нче яртысы), болгар галиме. Хәзер Гыйрак терр-ясенә кергән Мосул шәһәрендә яшәгән; фармакогнозия (дарулар белеме) өлкәсендә зур белемгә ия. «*әт-Тиръякъ әл-кәбир*» («Агуланулардан көчле дәва») трактаты авторы (1220–21 елларда Мосулда язылган). Ә.Б.*Халидов* аны «Мохтәсар фи мәгърифәт әл-әдвия» («Гади дарулар турында трактат», Мосул, 1219; 1222 дәге күчермәдә сакланган, Төркиянең Маниса шәһәрендә саклана) хезмәте авторы Таҗетдин бине Мөхәммәд Гали бине әл-Хөсәен әл-Болгари б-н тиңләштерә. Галим сүзләренә караганда «ул хәлифәләр дәүләтенең үзәк өлкәләре аксөяк мөселман

табибләре б-н аралаша». Т.б.Ю.әл-Б. хезмәтләрен күчереп язучылар аңа карата «абруйлы галим», «үз заманы уникумы», «ул дәвердә бердәнбер», «патшалар һәм солтаннар сәеклесе» сүзләрен кулланалар.

*Әд.* к. «*әт-Тиръякъ әл-кәбир*» мәкаләсен.

**ТАҖЕТДИ́НОВ** Әнәс Габдулла улы (23.2,1927, Чаллы кантоны Югары Налим а. — 25.6.1990, Казан), хакимият эшлеклесе, тарих фән. канд. (1971), ТАССРның атказ. юристы (1987). Казан ун-тын тәмамлый (1956). 1956–57 елларда Саба р-ны Икшермә МТСы партия ком-ты секретаре. 1957–58 дә КПССның Саба райкомы бүлек мөдире, 1958–59 да секретаре, 1962–63 тә КПССның Балтач райкомы 1 нче секретаре. 1956–62 дә КПССның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы, 1963–71 дә бүлек мөдире урынбасары. 1971–87 дә ТАССР юстиция министры. Т.ның хезмәтләре Татарстан партия оешмасының авылда мәдәни төзелешне оештыру мәсьәләләренә багышлана. 1980–85 тә ТАССР ЮС депутаты. Ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Великий Октябрь и культурная революция в Татарии. К., 1967; Культура села. К., 1968; За высокую культуру села. К., 1974.

**ТАҖЕТДИ́НОВ** Минсәет Тимергали улы (18.2.1960, Чуаш АССРның Батыр р-ны Чкалов а.), спортчы (грек-рим көрәше), Россиянең атказ. спорт остасы (2005). Спорт б-н 1973 елдан урта мәктәптә шөгыльләнә башлый; тренерлары — К.К.Йосыпов, Н.М.Алиев, 1977 дән — А.И.Винник (Ульянов ш.), А.Г.Мазур. СССР (1984), Европа (1984) чемпионы. СССР беренчелегендә (1981), И.Поддубный истәлегенә халыкара турнирларда (1985–86), Румыния (1979, 1981), Болгария (1983–84), Чехословакия (1984), Норвегия (1984–85), Германия (1985), Швеция (1985–86) турнирларында, Дөнья кубогына ярышларда (1984) җиңүче. СССР, Европа, дөнья чемпионатларында көмеш медаль (1985), СССР халыклары спартакиадасында (1983), СССР чемпионатында (1986) бронза медаль ала. 1977 дән Ульянов шәһәрендә яши.

**ТАҖЕТДИ́НОВ** Рәфыйк Зәкәрия улы (19.1.1961, Чүпрәле р-ны Иске Кәкерле а.), балалайкачы, педагог, ТРның халык артисты (2011). 1988 елда Казан мәдәният һәм сәнгать академиясен тәмамлый, 1987 дән шунда ук укыта. РФдә (Мәскәү, С.-Петербург һ.б.) һәм чит илләрдә (Көнбатыш Европа, Төньяк Африка илләре һ.б.) актив концерт эшчәнлеге алып бара, телевидение һәм радиода яздыра, аудио-, видеодисклар чыгара. Бөтенроссия халык инструментларында башкаручылар конкурсы (Магнитогорск, 1980), Германия (Клингенталь ш., 1993), Италия (Кастельфидардо ш., 1994), Франциядә (Андрезье-Бутеон ш., 1994) узган халыкара конкурслар (ш.и. Гран-при, алтын медальләр) лауреаты. Т.ның башкаруы югары профессиональлеге, виртуозлыгы, көчле эмоциональлеге һәм образлылыгы б-н аерылып тора. Репертуардагы балалайка өчен язылган барлык әсәрләрне дә (ш.и. үз әсәрләрен һәм көйләрен) башкара.

**ТАҖЕТДИ́НОВ** Ринат Арифҗан улы (1.1.1938, Чүпрәле р-ны Кече Чынлы а.), драма актёры, ТАССР, РСФСРның халык артисты (1973, 1982). 1961 елда М.С.Щепкин исем. Югары театр уч-щесен (Мәскәү) тәмамлый һәм Татар акад. театрында эшли башлый. Дивана («Ай тотылган төндә», М.Кәрим, 1965), Ильяс («Гүзәлем Әсәл», Ч.Айтматов, 1966; ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1967) кебек беренче рольләреннән үк үзен геройларының эчке дөньяларына тирәнтен үтеп керергә, теге яки бу персонажның күпкырлы характерын нечкә тоемларга һәм дөрес гәүдәләндерергә сәләтле актёр буларак таныта. Ильяс образында Т. аның яшьлек кызулыгын да, үз-үзенә ышанганлыгын, саф, чиста мәхәббәтен, мөлаемлыгын, шул ук вакытта үҗәтлеген, усаллыгын, ярсуын, рухи талчыгуын, үз хатасын танудан туган әрнү хисен оста гәүдәләндерә. Инсаф («Әни килде», Ш.Хөсәенов, 1970) ролен темперамент б-н башкара;




Р.А.Т а җ е т д и н о в Ильяс ролендә («Гүзәлем Әсәл», Ч.Айтматов; сулда — Н.Гәрәева).

Чешков («Чит кеше», И.М.Дворецкий, 1973) образында тышкы басынкылык һәм тыйнаклык артында яшеренгән эчке ялкынны, Искәндәр («Хуш, Назлыгөл!», М.Байҗиев, 1968) образында шәхеснең әхлакый яктан таркалу процессын, Эзоп («Кол», Г.Фигейредо, 1967) образында ирек өчен тормышыңны да аямаска әзер булу омтылышын тиешле югарылыкта яктырта. Истә калырлык сәнгатьчә чаралардан кыю файдаланучы киң диапазонга ия актёр буларак, Т. көчле драматик рольләрне дә (Надир мәхдүм — «Сүнгән йолдызлар», К.Тинчурин, 1971), сатирик рольләрне дә (Бәһави — «Һиҗрәт», Н.Исәнбәт, 1980) бертигез дәрәҗәдә ышандырырлык итеп башкара. М.Җәлил («Моңлы бер җыр», Т.Миңнуллин, 1981) образын «фикерләр драмасы» стилистикасында сәхнәгә чыгара: шагыйрьнең киеренке һәм дәвамлы фикерләү эшчәнлеген уңышлы гәүдәләндерә. Т. тудырган Карандышев («Бирнәсез кыз», А.Н.Островский, 1983) образы үзенчәлекле укылышы б-н аерылып тора: геройның, тәкәббер рәвештә үз-үзенә гашыйк



Р.З.Таҗетдинов.



Р.А.Таҗетдинов.

булып һәм горур кыяфәттә масаеп йөрүеннән алып, өметсез төшенкелеккә бирелүгә кадәр барып җитүе эзлекле үстерелә. Актёрның трагик Мирвәли («Өч аршын җир», А.Гыйләҗев, 1987), поэтик Галимулла («Хушыгыз!», Т.Миңнуллин, 1993), эпик Идегәй (шул исем. әсәр буенча, Ю.Сафиуллин, 1994), мәгънәсез Әнвәр («Мин төш күрдем», З.Хәким, 2000), сәеррәк Сократ («Баскетболист», М.Гыйләҗев, 2002) образлары тирән психологизм б-н сугарылган, аларның кылган гамәлләренә эзлеклелек хас. Т.ның зур рольләре арасында ш.у. Кол Гали (шул исем. әсәр буенча, Н.Фәттах), Тартюф (шул исем. әсәр буенча («Суган суфые»), Ж.Б.Мольер), Салих («Үзеңә хыянәт итсәң», Д.Вәлиев), Гыйльманов («Миңлекамал», М.Әмир), Абдулла Акчурин, Хәлиулла, Нургали, Нургазиз («Без китәбез, сез каласыз», «Илгизәр+Вера», «Шулай булды шул», «Дивана», Т.Миңнуллин), Хәнәви («Күрәзәче», З.Хәким), Ногман, Марат, Әнәс Әдрәсович («Мәхәббәт турында сөйләшик», «Әрем исе», «Бабайлар чуагы», И.Зәйниев), Чабар («Кара чикмән», Г.Хугаев), Клотальдо («Тәкъдир», П.Кальдерон), Бессеменов («Өзелгән өмет», М.Горький) һ.б. бар. Театр эшлеклеләре берлегенең Татарстан бүлеге рәисе (1988–2011). ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (1967), СССР Дәүләт бүләге (1986), РФ Театр эшлеклеләре берлегенең «Алтын битлек» («Золотая маска») Милли бүләге (2015), М.Сәлимҗанов исем. Респ-ка бүләге (2015) лауреаты.

*Әд.:* Илялова И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; Народные артисты. К., 1980.

*И.И.Илялова.*






Р.А.Т а җ е т д и н о в: 1. Карандышев («Бирнәсез кыз», А.Н.Островский); 2. Идегәй (шул исем. әсәр буенча, Ю.Сафиуллин) рольләрендә.

**ТАҖЕТДИ́НОВА** Гыйззениса Гайнетдин кызы (1894, Казан губ., Казан өязе Татар Әйшәсе а. — 5.12.1969, Казан), Казан губернасында хатын-кызлар хәрәкәтен оештыручыларның берсе. 1917 елга кадәр бертуган Кәримовлар басмаханәсендә эшли. 1917 дә Казан солдаткалар берлегенең мөселман хатын-кызлар бюросы әгъзасы һәм рәисе. 1918 нең җәендә Коммунистлар отряды сафларына керә, Казан КОМУЧның Халык армиясе гаскәрләре тарафыннан яулап алынганнан соң, В.М.Азин отрядында була, яралылар өчен госпиталь оештыруда катнаша. Шәрекъ халыклары коммунистлар оешмаларының Бөтенроссия съезды делегаты (Мәскәү, ноябрь 1918). 1920 еллар башында Татарстан авылларында җирле хакимият органнарын оештыру б-н шөгыльләнә. 1920 еллар уртасында Шәрекъ халыклары коммунистлар ун-тында (Мәскәү) укый, кайтканнан соң Казан совет партия мәктәбендә укыта. 1925 тән ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тында хатын-кызлар б-н эшләү бүлеге мөдире. «*Азат хатын*» ж-лын чыгаруда башлап йөрүче. Эшче хатын-кызларның 1 нче һәм 2 нче Бөтенроссия съездларында катнаша (Мәскәү), аларда К.Цеткин һәм Н.К.Крупская б-н очраша. 1930–50 елларда Казан шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары булып, партия һәм совет органнарында, халык мәгарифе системасында, кәсепчелек кооперациясендә эшли. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Д и б а е в а М. Тазетдинова Гиззениса Гайнутдиновна // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

**ТАҖИБА́ЕВ** Марат (19.2.1940, Казакъстан ССРның Кызыл Урда өлкәсе Казалы ш.), гамәли-бизәлеш сәнгате рәссаме, нәкышьче. Ш.Руставели исем. Ашхабад сәнгать уч-щесен (1960), В.И.Мухина исем. Ленинград югары сәнгать-сәнәгать уч-щесен (1969) тәмамлый. Рәссамнар берлеге (1988), халыкара «ITNET» текстиль берләшмәсе (АКШ, 1991), «Текстиль-Дизайн» ассоциациясе (С.-Петербург, 1993) әгъзасы, С.-Петербургта яши. 1969–92 елларда сәнгать фондында эшли. Т. — әйдәп баручы гобелен осталарының берсе, табигый материалларны (йон, мамык) кулдан туку техникасында, ясалма киезләрне аппликацияләү, катнаш һ.б. техникада башкарылган сюжетлы келәмнәр авторы. Аның гобеленнары ритмик динамика, кинаяле сәнгать теле, контрастлы төсләр гаммасы, композицияләрдәге чынбарлыктагыча сурәтләүнең абстракт һәм схематик алымнарга каршы куелуы б-н аерылып тора: «Ел фасыллары» циклы (1980 еллар), «Су энергиясе» (1987), «Евразия» (1993), «Инфляция» (1994), «Музыкаль пауза» (1995), «Ике тоткын», «Сәламәтлек саклау министрлыгы кисәтә» (икесе дә — 1996), «Җитди фикерләр», «Төсле фикерләр» (икесе дә — 2001), «Үзәнлек бүләкләре» (2004), «Ялангач кыз» (2005), «Карбызлы натюрморт» (2007), «Хәтер чоңгылы» (2009). Батик техникасында башкарылган панно, театр һәм интерьер пәрдәләре авторы: «Конструктив шәһәр» (1990), «Күгәрчен» (1991) һ.б. Т. нәкышь портретлары: «РФнең халык артисты В.Татосов» (2008), «РФнең атказанган рәссамы Ә.Зарипов», «Композитор С.Осколков» (икесе дә — 2009); пейзажлар: «Грибоедов каналы» (2005), «Картиналар йорты. Ораниенбаум» (2008); натюрмортлар: «Көз», «Керәч һәм җиләк-җимеш» (барысы да — 2008); жанрлы картиналар: «Алло! Элемтә музееммы?» (2007); рәсемнәр (күмер, карандаш): «А.Заславский портреты», «Сугыш фәзасы» (икесе дә — 2007) иҗат итә.



М. Т а җ и б а е в. «Су энергиясе» триптихы. Үзәк өлеше. Гобелен. Йон. Шома тукыма. 1987. Саян-Шушенский ГЭСының конференц-залы.

Шәһәр — Манежда Петербург рәссамнары (1994 тән); бөтенроссия — гамәли-бизәлеш сәнгате (Мәскәү, 2008); халыкара — гобеленнар кучмә күргәзмәсе (АКШ, 1992), ел саен үткәрелә торган «Сергей Осколков һәм аның дуслары» сәнгать фестивале (С.-Петербург, 2003 тән); бөтентатар — «Татарт» (С.-Петербург–Казан, 1991), «Казанның 1000 еллыгы» (С.-Петербург, 2005), С.-Петербургтагы татар милли-мәдәни автономиясе рәссамнарының «Рәссамнар — шагыйрьләргә» (2006) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Лунд (Швеция, 1992) һәм С.-Петербург шәһәрләрендә (2008, 2009, З.Ревчук б-н берлектә) үткәрелә. Әсәрләре С.-Петербург тарихы музеенда, А.С.Попов исем. Үзәк элемтә музеенда (С.-Петербург), «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Анкоридж шәһәренең Тарих музеенда (АКШ), Россия һәм чит илләрдәге шәхси тупланмаларда саклана. 2006–07 дә иҗат иткән гобеленнар сериясе өчен САнең дипломы б-н бүләкләнә (2009).

*Әд.:* В ә л и е в а - С ө л ә й м а н о в а Г. Күгәрчен гөрлидер // Казан утлары. 1993. № 5; Artindex. Художники Петербурга: Каталог-справ. СПб., 2003; Ё ж и к о в Д. Andante, Andante // Новый Мир Искусства. 2000. № 4.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*



М. Т а җ и б а е в. «Музыкаль пауза». Гобелен. Йон. Мамык. Шома тукыма. 1995.

**ТАҖИ́ЕВ** Рәфкать Минһаҗ улы (1.5.1943, Бондюг р-ны Бәзәкә а.), хирург-онколог, мед. фән. д-ры (1998), проф. (1998), ТРның атказ. табибе (1995), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). Проф. М.З.*Сигал* шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1966), Чуаш АССРның Яльчик үзәк район хастаханәсендә баш табиб булып эшли. 1969 елдан Казан мед. академиясенең хирургия һәм онкология кафедрасында (бүленеп: 1971–81 дә Респ-ка онкология диспансерында абдоминаль һәм торакаль онкология бүлеге мөдире), 1993 тән каф. мөдире, 1998 дән каф. профессоры. Хезмәтләре яман шеш авыруларын дәвалауда хирургия ысулларын камилләштерү мәсьәләләренә карый. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2011), ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының «Ел табибе — Ак чәчәкләр» Респ-ка бүләге лауреаты (2013). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Озонотерапия в раннем послеоперационном периоде при хирургическом лечении рака лёгкого // Казан. мед. журн. 2000. № 4 (автордаш); Опыт лечения первично-множественного базально-клеточного рака кожи глицифоновой мазью // Вопр. онкологии. 2002. № 6 (автордаш); Рак пищевода: хирургическое и комбинированное лечение // Рос. онкологический журн. 2002. № 1 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Тазиев Рафкат Мингазович // Казан. мед. журн. 2003. № 3.

**ТАҖИ́ЕВ** Фаиз Сәләхетдин улы (7.5.1941, Тымытык р-ны Күк Тәкә а.), агроном, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (2000). Минзәлә совхоз-техникумын тәмамлый (1970). Азнакай р-нында механизатор (1963 елдан), бригадир (1970 тән), «Авангард» к-зында (1990 нан), «Яланкүл» а.х. җитештерү кооперативында (1992–2005) баш агроном булып эшли. Дәүләт бүләге бөртекле культуралардан югары уңыш алганы өчен бирелә. СССР ВДНХсының ике көмеш, бер бронза медале б-н бүләкләнә.

**ТАҖИ́ЕВ** (Tazieff) Һарун Нәкыйп улы (11.5.1914, Варшава — 2.2.1998, Париж), Бельгия һәм Франция геологы, вулканолог, дәүләт эшлеклесе, проф. (1973). Льеж ун-тын тәмамлый (Бельгия; 1944). Катанга (Бельгия Конгосы) аккургаш рудникларында эшли. 1952–62, 1972–81 елларда Франция Милли фәнни-тикшеренү һәм вулканология үзәгендә (Париж), директор (1972 дән). 1962 дә Италиядә Вулканология милли ин-тын оештыра. 1984–86 да Франция премьер-министры каршында дәүләт секретаре, бер үк вакытта Париж Җир физикасы ин-тында бүлек җитәкчесе, 1988–95 тә Вулкан хәвеф-хәтәрләре югары ком-ты президенты. Хезмәтләре вулканология, сейсмология, геология, минерал. өлкәләренә карый. Планета вулканнары турында фильмнар авторы. Т. дөньяның төрле төбәкләрендәге вулканнарны өйрәнә, вулкан магмасы төрләрен һәм Җир өслегендә вулканнарның урнашу закончалыкларын билгели. Каршылык хәрәкәтендә катнаша

(1940–44). 1989 елда «Елның иң яхшы французы» дигән исемгә лаек була.

Х е з м.: Вулканы. М., 1963; Запах серы. М., 1980; На вулканах Суфриер, Эребус, Этна. М., 1987.

**ТАҖИ́ЕВА** Клара Сабир кызы (25.6.1941, Үзбәкстан ССР, Әндижан ш.), музыка белгече, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991). Композиторлар берлеге әгъзасы (1989). 1968 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1969–79 да ТАССР МС каршындагы Радио һәм телевидение дәүләт ком-тының муз. мөхәррире, 1979–81 дә ТАССР Композиторлар берлегенең җаваплы сәркәтибе, 1981–97 дә Татар филармониясенең лектор-музыка белгече. Респ-каның муз. культура эшлеклеләренә багышланган күп кенә радиотапшырулар, циклы «Музыкаль Татарстан» («Музыкальный Татарстан»), «Композиторлар белән очрашулар» («Встречи с композиторами»), «Күңелле баскычлар» («Весёлые ступеньки») радиотапшыруларын алып бара, радиоконцерт программалары төзи, Татар радиосы фондлары өчен ТАССР композиторларының яңа муз. әсәрләрен яздыруны оештыра. Концертлар алып баручы буларак танылa. Композитор М.Мозаффаровның тормышын һәм иҗатын өйрәнә. Матбугатта муз. сәнгатьнең актуаль проблемаларын яктырта.

Х е з м.: Башка берни дә кирәкми. К., 2006; Мансур Музафаров. К., 1993; Рустем Яхин: материалы, письма, воспоминания. К., 2002 (автордаш).

*Ф.Ш.Салитова.*

**ТАҖИ́ЕВА** Миңнесәгыйрә Таҗи кызы (6.8.1936, Минзәлә р-ны Кузкәй а. — 3.1.2009, Тукай р-ны Татарстан пос.), зоотехник, Соц. Хезмәт Герое (1971), ТАССРның атказ. терлекчесе (1985). Минзәлә совхоз-техникумын тәмамлый (1973). 1953–75 елларда Тукай р-нының «Татарстан» с-зында эшли: сыер савучы, зоотехник (1972 дән). 1975–91 дә «Сосновоборский» дуңгызчылык комплексында: терлек азыгы лаб-ясе мөдире, репродукция фермасының 1 нче участок башлыгы (1978 дән), зоотехник-селекционер (1989 дан). Т. һәр сыердан уртача еллык савымны 2391 *кг* нан (1966) 3890 *кг* га (1970) җиткерүгә ирешә. 1969 да «Районның иң яхшы сыер савучысы» дигән мактаулы исемгә лаек була. 1986–90 да Т. җитәкләгән участокта дуңгызлардан 124,4 мең үрчем, 5170 *т* артым алына. Герой исеме а.х. җитештерүендә, игенчелек һәм терлекчелек продукциясе сатуның бишьеллык (1966–70) планын үтәүдә ирешкән уңышлары өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә. Респ-каның Ленин юбилей Хезмәт Даны китабына (1970), КПССның Татарстан өлкә ком-ты, ТАССР МС, Профсоюзларның Татарстан өлкә советының Мактау китабына (1985) кертелгән.

*Әд.:* Б е л о к о п ы т о в В. Тазеева Миннисагира Тазеевна // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой славы — наши земляки. К., 2003.

**ТАҖИ́К ЕРМАГЫ́** («Тезицкий ров»), тирән чокыр; башка мәгълүматларга караганда, Казан кальгасы терр-ясендәге ясалма саклану корылмасы. 21 йөз башы археол. мәгълүматлары буенча (А.Г.Ситдыйков), ермак 10–11 йөзләрдә барлыкка килгән һәм хәзерге Казан Кремле терр-ясендә болгарлар яшәгән торулыкның көньяк чиге булып торган. Киңлеге 14 *м* чамасы, тирәнлеге 4 *м* чамасы булган, аның төньягында керү капкалары б-н ур сузылган. 15 йөз уртасына ермакның тирәнлеге кимеп, 3 *м* га, соңрак 1,5 *м* га калган. Т.е. атамасы Никон елъязмасында, «Казан шәһәренең 1565–1568 еллардагы писцовый кенәгәсе»ндә, ш.у. кенәз А.М.Курбский истәлекләрендә очрый; Урта Азиядән, Персиядән, Әрмәнстаннан килгән көнчыгыш сәүдәгәрләрен аңлаткан «таҗик» сүзеннән килеп чыккан (сәүдәгәрләрнең йортлары ныгытма терр-ясендә ермак янында урнашкан, алар үзләре «Гостиный двор»да сәүдә иткәннәр). 1552 елда әлеге сәүдәгәрләрнең казанлылар б-н бергә шәһәрне камап алган рус гаскәрләренә каршы сугышуы мәгълүм. 18–21 йөзләрдәге Казан тарихчылары арасында Т.е.ның урыны турында уртак фикер юк. С.М.Шпилевский, П.Е.Заринский, Н.Я.Агафонов фикеренчә, ул хәзерге Спас манарасы каршында булган, әлеге галимнәр аны олы ермак (аның аркылы 19 йөздә күпер салына) б-н тиңләштерәләр (ермак 20 йөздә күмелә, аның эзләре шәһәр хакимияте бинасы каршындагы 1 Май мәйданында һәм Бауман урамына төшү урынында күренә). Н.Ф.Калинин ермак соңрак төзелгән Киприан һәм Устиния чиркәүләре тирәсеннән, Казан кальгасының Олы һәм Түбән капкалары яныннан сузылган дип исәпли. А.Г.Ситдыйков һәм Р.И.Солтанов фикеренчә, ермак Благовещение соборы янындагы хәзерге сквер буйлап урнашкан. Алар фаразларын алга сөргәндә археол. казу эшләре нәтиҗәләренә таяналар, казулар барышында корылмалар комплексы табыла, аны Колшәриф мәчете калдыклары дип уйлыйлар. Никон елъязмасында мәчет Т.е.ннан ерак түгел: шәһәрне штурмлаган вакытта христианнар «Колшәриф мәчете янына, Таҗик ермагы янына» якынлашалар диелә. Ул урындагы зур сугышта сугышчылар, шәкертләр, Колшәриф сәед үзе дә һәлак була. Т.е.ның урыны турындагы бәхәсләр Казан кальгасында берничә ермак булуы б-н аңлатыла. Үзенең язмаларында кенәз А.М.Курбский Арча кыры ягыннан казып кереп шартлатылган урында «казан патшасының үз даирәсе б-н якынча ярты шәһәрне (кальганы) калдыруы һәм Т.е.нда ныклап урнашуы... шәһәрнең ике өлеше, тигезлектәге кебек, тауда урнашкан, ә өченче өлеше бик түбәндә, упкында кебек. Ә аркылы, ярты шәһәргә диярлек, Болактан башлап, шәһәрнең иң түбән өлешенә кадәр зур ермак» булуы турында яза. Димәк, Т.е. кальгада, төп мәчет янында урнашкан була. Соңгы тапкыр ермак исеме «Казан шәһәренең 1565–1568 еллардагы писцовый кенәгәсе»ндә искә алына, аның урыны Кремльнең Преображение (көнбатышта) һәм Дмитрий (көнчыгышта) капкалары арасында дип күрсәтелә. П.Е.Заринский аңлатуынча, Дмитрий капкасы «Архиерей йорты һәм Консистория арасында» була. 16 йөз ахырында, Фёдор Иоаннович патшалык иткән дәвердә, тузган агач диварларга алмашка



М.Т. Таҗиева.

Кремльдә таш диварлар төзелеше алып барыла һәм Благовещение соборы янындагы терр-я төзекләндерелә, Т.е. күмелә.

*Әд.:* К а л и н и н Н.Ф. Казань, К., 1955; С у л т а н о в Р.И. Историческая география Казани (город и его предместья в XVI–XVII веках). К., 2004; Знаменитые люди о Казани и Казанском крае. К., 2005; С и т д и к о в А.Г. Казанский кремль: Ист.-археол. исслед. К., 2006.

*М.В.Недорезов.*

**ТАЗ** (пeләш, хәйләкәр), татар халык әкиятләре персонажы. Тылсымлы («Батыр егет»; «Таз — патша кияве») һәм гаилә-көнкүреш («Хәйләкәр Таз») әкиятләрендә очрый. Т. — уңай персонаж, зирәк һәм хәйләкәр. Вакытлар үтү б-н, *мәзәкләр* персонажына әверелә: ахмаграк итеп күрсәтелә. Казакълар (Тазша) һәм Алтай халыклары (Тас-Таракай) фольклорында да очрый.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Әкиятләр: 3 китапта. К., 1977–81; Исторические корни волшебной сказки. Л., 1946.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ТАЗАЧИШМӘ́** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 20 *км* көньяк-көнбатыштарак, Камышлы елгасының (Минзәлә елгасының сул кушылдыгы) уң кушылдыгы буенда. 1925–26 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чаллы кантоны Сарман волостенда. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1926 да — 104, 1938 дә — 166, 1949 да — 160, 1958 дә — 121, 1970 тә — 105, 1979 да — 49, 1989 да — 12 кеше; 2002 дә даими яшәүчеләр юк.

**ТАЗЮКО́В** Фәрук Хөснетдин улы (7.1.1951, Казан), теоретик механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2001). 1973 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1973–82 дә — Казан авиация ин-тында, 1982–89 да — «Вакууммаш» ФҖБдә, 1989 дан РФА КГҮдә: Физика-техника ин-тында (1989–91), Механика һәм машиналар төзү ин-тында (1991–97) эшли. 1997 дән Казан технол. ун-тында, теоретик механика һәм материаллар каршылыгы каф. профессоры (2001 дән). Хезмәтләре физик-химик гидродинамикага, теоретик һәм гамәли реологиягә карый. Фәнни-тикшеренү нәтиҗәләре ТРның химия һәм нефть химиясе пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Theoretical and experimental investigation of rarefied gas flow in molecular pumps Systems // Vacuum in Forschung und Praxis. 1995. V.7, № 1 (автордаш); Surface Migration of Oil in Vacuum Systems // Vacuum in Forschung und Praxis. 1996. V.8, № 2 (автордаш); Flow Structure in Special Channel Having Step and Obstacle // Fluid Flow Research: Turbulence and Applied MHD. 1998. V.182 (автордаш).

**ТАИ́РОВ** Наил Измаил улы (2.2.1952, Ульянов өлкәсенең Барыш р-ны Калны а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2012), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2002). Ульянов пед. ин-тын тәмамлый (1973). 1973–75 елларда Ульянов өлкәсе мәктәпләрендә тарих укытучысы. 1978 дән Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тында. Хезмәтләре татар зыялылары, Идел буе һәм Урал алды татар эшмәкәрләренең сәүдә-сәнәгать, хәйрия һәм иганәчелек эшчәнлеге тарихына (19 йөзнең 2 яртысы — 1917) карый.

Х е з м.: Акчурины. К., 2002; Организационно-методический опыт кафедры истории Отечества и зарубежных стран: Пособие для преподавателей вузов. К., 2010 (автордаш).

**ТАЙ́С**, к. *Татарстан интеллектуаль милек агентлыгы.*

**«ТАИФ»**, күп тармаклы, интегральләштерелгән компанияләр төркеме (КТ), ТРда иң зур һәм РФдә иң зурларның берсе. 1991 елда нигезләнгән «Казан» ФҖБ җирлегендә 1995 тә «Т.» АҖ буларак оештырыла. 2015 тә финанс, техника, технология, идарә мөнәсәбәтләрендә үзара тыгыз бәйләнгән 54 бүлендек һәм бәйле компанияләрне берләштерә (эшләүчеләрнең гомуми саны 43 меңнән артык). «Т.»ның төп эшчәнлек төрләре: нефть һәм газ эшкәртү, нефть химиясе һәм химия сәнәгате, энергетика (29 компания, ш.и. «ТАИФ-НК», «*Түбәнкаманефтехим*», «Казаноргсинтез», «*Л.Я.Карпов исем. химия заводы*», «Түбән Кама 3 нче монтаж идарәсе» АҖләре), төзелеш һәм төзелеш материаллары җитештерү (6 компания, ш.и. «ТАИФ-СТ», «Казан силикат стена материаллары заводы», «Керамика-Сервис» ҖЧҖләре), телекоммуникацияләр, масс-медиа, комплекслы хезмәт күрсәтүләр һ.б. (15 компания, ш.и. «ТВТ», «Яңа гасыр» телерадиокомпанияләре, «ТАИФ-Арт», «Кекин йорты» АҖләре, «Карсар» ҖЧҖ), инвестицияләр һәм финанс (6 компания, ш.и. «ТАИФ», «ТАИФ-Инвест» АҖләре, «ТЕЛЕКОМ-Менеджмент», «ТАИФ-Финанс» ҖЧҖләре).

«Т.» ТР һәм РФ икътисады өчен өстенлекле әһәмияткә ия зур инвестиция программаларын гамәлгә ашыра (үз акчалары һәм әйдәп баручы Россия һәм халыкара кредит учреждениеләреннән алынган акчалар хисабына); дөнья стандартларына туры килгән яңа төр продукция һәм хезмәт күрсәтүләр



«ТАИФ» ААҖнең Казандагы төп бинасы.

булдыручы югары технологияле инновацион проектлар эшли һәм гамәлгә кертә; пр-тиеләрнең агымдагы эшчәнлеге б-н идарә итә, аларны финанслый һәм үстерә; социаль җаваплылык б-н бизнес алып бара.

Нефть-газ химиясе өлкәсендә «Т.» ТРда нефть-газ химиясе комплексын үстерүнең Президент программасы нигезендә углеводород чималын тирәнтен эшкәртү буенча зур масштаблы инвестиция проектларын тормышка ашыра. 1997–2009 да «ТАИФ-НК» АҖ з-длары комплексы төзелә (эшләүчеләр саны 2,7 меңнән артык), аларда нефть, газ конденсаты, табигый битумнар эшкәртелә, Евро-4 халыкара экология стандартларына туры килгән автомобиль бензиннары һәм дизель ягулыгы (елына 3 млн. *т* га кадәр), нефть химиясе өчен чимал (2 млн. *т*), авиакеросин (600 мең *т*), юллар салу өчен битум (120 мең *т*) һ.б. чыгарыла. «ТАИФ-НК» респ-када беренче тапкыр нефтьне тирәннән эшкәртә башлый, «Т.»ның нефть химиясе пр-тиеләре өчен иң зур чимал бирүчеләрнең берсе булып тора. РФ нефть эшкәртү тармагы җитештергән гомуми продукция күләмендә: турыдан-туры куылган бензинның 10%ы, дизель ягулыгының 2,9% ы, автомобиль бензинының 1,5% ы «ТАИФ-НК»га туры килә.

2003–08 дә «Казаноргсинтез» АҖне стратегик үстерү программасы кысаларында линияләп полиэтилен, поликарбонатлар җитештерү һәм бисфенол-А синтезлау башлана (икесе дә — Россиядә бердәнбер). 2005–09 да «Түбәнкаманефтехим» АҖдә полипропилен, полистирол (Россиядә иң эреләр), полиэтилен җитештерү җайга салына, бутил һәм галобутилкаучуклар чыгару куәте арттырыла, газ турбиналы электр энергиясе җайланмасы куела. РФ нефть химиясе тармагы җитештергән гомуми продукция күләмендә: полиэтиленның — 51% ы, полистиролның — 70% ы, полипропиленның — 33% ы, поликарбонатның — 100% ы, синтетик каучукларның 57,6% ы «Т.»ка туры килә. 2006 да Л.Я.Карпов исем. химия з-дында заманча нәтиҗәле җылылык изоляцияләү материалы (экструдирланган пенополистирол) җитештерү сафка кертелә.



Түбән Кама нефть эшкәртү заводы. Гомуми күренеше.

Мәгълүмат технологияләре һәм телекоммуникацияләр өлкәсендә «Т.» КТ пр-тиеләре, 1990 еллар ахырыннан башлап, респ-ка терр-ясенең күпчелек өлешен колачлаган күчмә «Сантел» кәрәзле элемтә челтәрен булдыра, «Казанның мультимедиа челтәре» проектын гамәлгә ашыра, Казанда 2 һәм Бөгелмәдә 1 цифрлы АТСны сафка кертә, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе җирлегендә респ-ка телерадиотапшыруларының зур масштаблы системасы (ш.и. спутниклы) оештырыла. Хезмәт күрсәтүләр һәм сәүдә тармагында Казанда «*Пирамида*» мәдәни-күңел ачу комплексы ачыла (2002), федераль әһәмияткә ия *Кекин йорты* мәдәни мирас объекты реставрацияләнә һәм реконструкцияләнә (2000–04). Яңа төзелгән сәнгать һәм гражданлык объектларының зур күпчелеген «Т.» КТнең төзелеш пр-тиеләре сафка бастыра. Алар ш.у. *Тузган торакны бетерү программасын* һ.б. социаль әһәмияткә ия программаларны гамәлгә ашыруга зур өлеш кертә, Казанда Балалар клиника-диагностика үзәген (2001), ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы бидалары комплексын, ш.и. ТР Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе бинасын (2005), ТР Пенсия фонды бинасын (2005), Чирәмдәге хоккей үзәген (2007), Казан, Бөгелмә һәм респ-каның башка шәһәрләрендә күп кенә зур сәүдә-күңел ачу үзәкләрен төзеп, файдалануга тапшыралар.

«Т.»ның финанс өлкәсендәге мөһим чараларына «Казаноргсинтез» АҖ акцияләрен халыкара фондлар базарына чыгаруны (1999), РФ Саклык банкы б-н «Казаноргсинтез» АҖне стратегик үстерү программасын финанслау (840 млн. доллар күләмендә) буенча килешү төзүне (2004), 4 млрд. сумлык «ТАИФ-Финанс» ҖЧҖ облигацияләрен чыгаруны (2006), «ТАИФ-НК» АҖ өчен 500 млн. доллар күләмендә ING Bank N.V.дан (Нидерланд) кредит алуны (2008) кертергә мөмкин.

2013 тә сәнәгый максатлардагы 129 бина (гомуми мәйданы — 198253 $м^2$) файдалануга тапшырыла, дизель ягулыкны гидрочистарту (елга 2 млн. *т*), газ эшкәртү (елга 140 млн. $м^3$), кирпеч җитештерү (елга 5 млн. дана) куәтләре сафка баса.

«Т.» КТнең гомуми кереме 2014 тә – 461,9 млрд. сум, 2015 тә 524,2 млрд. сум тәшкил итә. Төрле дәрәҗәдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга 63,3 млрд. сум салымнар һәм җыемнар җибәрелә. Төп фондларга 69,5 млрд. сумлык инвестиция кертелә.

«Т.» КТ пр-тиеләре («ТАИФ-НК» АҖ бензин з-ды, «ТАНЕКО» АҖ нефть эшкәртү з-длары комплексының беренче чираты, тоташ металл кордлы шиннар з-ды (барысы да — Түбән Камада), «ИНВЕНТ» компанияләр төркеменең кабель, электр техникасы һәм торбалар продукциясен җитештерүче з-длары, «Нәфис» компанияләр төркеменең май экстракцияләү һәм май з-длары (барысы да — Казанда) һ.б.) — дәрәҗәле халыкара, бөтенроссия һәм респ-ка бүләкләре, конкурс һәм күргәзмәләре лауреатлары; күп ке-

нә хезмәткәрләр дәүләт бүләкләренә лаек була.

*Әд.:* Татарстан: Спец. вып., посвящ. «ТАИФ», 2006. № 10.

**ТАЙШЕВ** Марсель Мазһар улы (2.1.1943, Сарман р-ны Сарман а.), мәдәният эшлеклесе, тарих фән. канд. (1984), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1992). Казан химия-технол. ин-тын (1967), КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясен (Мәскәү, 1984) тәмамлый. 1967–71 елларда Казан органик синтез з-дының ВЛКСМ ком-ты секретаре. 1971–72 дә ВЛКСМның Казан шәһәре Ленин райкомы секретаре. 1972–73 тә ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты секретаре. 1973–78, 1984–85 тә КПССның Татарстан өлкә ком-тында мәдәният бүлеге мөдире урынбасары. 1978–81 дә Татарстан мәдәният хезмәткәрләре профсоюзлары өлкә ком-ты рәисе. 1985–99 да ТРның мәдәният министры. 1999–2005 тә ТР Премьер-министры киңәшчесе. Язмалары Татарстанда сәяси мәдәният формалашу мәсьәләләренә багышлана. 1985–90 да ТАССР ЮС депутаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ТАЙГУҖА́** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 26 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Дөреш елгасы буенда. 2010 елда 160 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1680 нән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Дөреш исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп (1841 дә ачыла), су тегермәне, ашлык саклау-сату кибете була. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 1644,2 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1795 тә — 80 ир-ат; 1836 да — 275, 1859 да — 389, 1870 тә — 432, 1887 дә — 699, 1905 тә — 937, 1920 дә — 946, 1926 да — 959, 1938 дә — 770, 1949 да — 704, 1958 дә — 504, 1970 тә — 431, 1979 да — 236, 1989 да — 187, 2002 дә — 196 кеше.

**ТАЙДУЛА́** бикә (? — 1360 тирәсе), ханбикә. Алтын Урда ханы *Җанибәк*, аның үлеменнән соң — *Нәүрүз хан* хатыны. Православие руханиларына хәерхаһлык күрсәтә; митрополитлар Иоанн (1347), Феогност (1351) һәм Алексийга (1354) ярлыклар биргәнлеге мәгълүм. Нәүрүз ханны тәхеттән төшергәндә һәлак була. Кайбер фаразлар буенча, Тула шәһәренең килеп чыгышы Т. ханбикә исеме б-н бәйле.

**ТА́ЙСИН** Әнвәр Сафа улы (10.10.1920, Пермь губ., Пермь өязе Куян а. — 29.5.2010, Казан), географ, педагог, пед. фән. д-ры (1999). Пермь пед. ин-тын тәмамлый (1947). 1948–2009 елларда Казан пед. ин-тында (2005 тән — Татар гуманитар-пед. ун-ты, 2010 нан Казан ун-ты), физик геогр. һәм геол. каф. профессоры (1999 дан); бер үк вакытта, 1993–97 дә, ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында геогр. һәм геол. бүлеге мөдире. Хезмәтләре Идел-Кама саклаулыгы ландшафтларын, күлләр эволюциясен, аларның эрозия-аккумулятив процесслар йогынтысында хәзерге үзгәрешләрен өйрәнүгә карый. Т. Казан тирәсендәге күлләрнең морфологик һәм морфометрик характеристикасын эшли. Урта мәктәпләр өчен «Татарстан географиясе» («География Татарстана») дәреслеге (20 дән артык басмасы дөнья күрә, 1961–2009), ТР мәктәпләрендә укытуның төбәк принципларын тормышка ашыру буенча уку-укыту методик ярдәмлекләре авторы. Татар энциклопедиясенең Генераль лөгатьлеген һәм сүзлеген эшләүгә зур өлеш кертә, Татарстан географиясенә караган күп кенә мәкаләләр авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О влиянии рельефа на природные территориальные комплексы Раифы // Тр. Волжско-Камского гос. заповедника. 1972. Вып. 2; Озёра Приказанского района, их современные природные и антропогенные изменения. К., 2006; Раифский лес в составе бореальных лесов Евразии. К., 2008.

**ТА́ЙСИНА** Эмилия Әнвәр кызы (10.4.1951, Казан), философ, лингвист, филос. фән. д-ры (1994), проф. (1996). РФнең Мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2008). ТРның фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт бүләге лауреаты (2014). 1973 елда Казан пед. ин-тының (хәзер Казан (Идел буе) федераль ун-ты) чит телләр ф-тын тәмамлый, шунда ук эшли. Бер үк вакытта, 2000 нән, Казан энергетика ун-тында коммуникацияләрнең теоретик нигезләре каф. мөдире. Хезмәтләре лингвосемиотика, гносеология (танып белү теориясе), социаль филос. һәм социол., коммуникацияләр теориясе өлкәләренә карый.

Х е з м.: Философские вопросы семиотики: Гносеологические аспекты. К., 2003; Очерки новой гносеологии: В 4 ч. К.–СПб., 2009–2014.


**ТАЙСУГА́Н** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 14 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Дала Зәе елгасы буенда. 2010 елда 1229 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөз башында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, умартачылык, сәүдә, төрле кәсеп б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да 2 мәчет (1931 һәм 1939 га кадәр эшли), мәдрәсә, мәктәп, кыз балалар мәктәбе (1883 тә ачыла), 2 су тегермәне, бакалея кибете эшли. Тайсуган мәдрәсәсе 18 йөз – 20 йөзләр башындагы иң атаклы мөселман уку йортларының берсе була, анда *Батырша* һ.б. күренекле дин эшлеклеләре белем ала. 1910 елгы мәгълүматларга караганда, авыл җәмәгатенең имана җире 2815 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Микулин волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1746 да — 46, 1762 дә — 67 ир-ат; 1795 тә — 394; 1816 да — 539, 1859 да — 1163, 1889 да — 1450, 1897 дә — 1775, 1910 да — 2008, 1920 дә — 2282, 1926 да — 2258, 1938 дә — 1909, 1949 да — 1514, 1958 дә — 1558, 1970 тә — 1506, 1979 да — 1249, 1989 да — 1014, 2002 дә — 1170 кеше.

**ТАЙСУГАНЫ́Й** Габдрахман Туймөхәммәд угылы (1691, хәзерге Сарман р-ны Мортыштамак а. — 1763 елдан соң, хәзерге Әлмәт р-ны Тайсуган а.), дин эшлеклесе, шагыйрь. Тайсуган авылы мәдрәсәсенең җитәкчесе һәм мөдәррисе. Күпсанлы шәкертләре һәм дәвамчылары була. Шигъри иҗатыннан *касыйдә* жанрында язылган бер шигыре билгеле. Ул беренче мәртәбә Р.Фәхретдиннең «Асар» хезмәтендә дөнья күрә (Оренбург, 1904). Р.Фәхретдин мәгълүматларына караганда, 1728 дә Т. балаларына, туганнарына һәм шәкертләренә васыять яза. Анда ул дини һәм дөньяви мәсьәләләргә карата үзенең киңәшләрен биреп калдыра: фән б-н шөгыльләнергә, туганнарны хөрмәт итәргә, тату яшәргә, бер-берләренә ярдәмләшергә, наданнар б-н аралашмаска өнди. Хаттат буларак та билгеле.

*Әд.:* Ф ә х р е д д и н Р. Асар. К., 2006.

*А.М.Ахунов.*

**ТАЙТОЯ́К** (Asarum), кирказончалар семьялыгыннан мәңге яшел күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 100 гә якын төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — Европа Т.ы (A. europaeum) бар; барлык районнарда да очрый. Киң яфраклы һәм ылыслы-киң яфраклы урманнарда үсә. 5–10 *см* биеклектәге үсемлек, шнурсыман шуышма тамырчалы һәм шуышма ботаклы, ботак очларында озын сапллы, кара яшел төстәге өсте ялтыравыклы һәм аскы ягы кыска төкчәле 2 яфраклы, формасы буенча тоякны хәтерләтә (исеме шуннан). Яфраклары яшел килеш кышлый. Чәчәкләре коңгырт яшел төстә, берле, иенке кыска сапларда утыралар. Җимеше — күп орлыклы, алты оялы түгәрәк тартмачык. Үсемлектән борыч исе килә, шунлыктан хайваннар аны бик ашамый. Майда чәчәк ата. Җимешләре июньдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Тамырчасында, тамыр һәм яфракларында алкалоид, гликозид, эфир мае, органик к-талар бар. Халык медицинасында тамырча һәм тамырларыннан ясалган төнәтмәсе костыргыч, какырык куптару, бәвел кудыру чарасы буларак кулланыла. Агулы декоратив үсемлек.



Европа тайтоягы.

**ТАЙЧИ́НОВ** Марат Гали улы (10.1.1930, БАССРның Әлшәй р-ны Гайнәямак а.), педагог, пед. фән. д-ры (1987), проф. (1992), БРның атказ. фән эшлеклесе (1995). Башкорт

пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), БАССР урта мәктәпләрендә укытучы, директор булып эшли. 1968 елдан СССР ПФАнең фәнни тикшеренүләрне координацияләү советы гыйльми секретаре. 1976 дан СССР ПФАнең Һөнәри юнәлеш һәм хезмәткә өйрәтү фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү), 1977 дән СССР ПФАнең Гомуми һәм пед. психол. фәнни-тикшеренү ин-тында, 1992 дән РФ Мәгариф министрлыгының Милли проблемалар ин-тында, 1999 дан РФ Фән һәм мәгариф министрлыгының Гомуми белем бирү ин-тында (хәзер Мәгарифне үстерү ин-ты). 2002 дән Урта һөнәри белем бирүне үстерү проблемалары ин-тының пед. һәм тәрбия психологиясе каф. мөдире, 2007 дән Мәскәү Мәгариф департаментының һөнәри белем бирү буенча укыту-методик үзәгендә баш белгеч. Үсмерләрнең һәм яшьләрнең шәхес үсеше проблемаларына, милли үзаң тәрбияләү һәм этник мәдәният формалаштыруга караган хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Проблемы формирования нравственного сознания и поведения подрастающего поколения. А.-А., 1975; Воспитание и самовоспитание школьников: Книга для учителя. М., 1982; Личность и её становление. Киев, 1990 (автордаш); Формирование личности учащихся на духовно-нравственных ценностях народа. М., 1999; Традиционные ценности народов России и их интеграция в современной системе образования. Нижнекамск, 2006.

**ТАКМА́К**, татар муз.-поэтик фольклор жанры; кызу темп б-н башкарыла торган, күбрәк мәхәббәт турында, еш кына иҗтимагый эчтәлекле, рифмалашкан кыска (гадәттә, 4 юллык) җыр. Т.ларның барлыкка килүе һәм таралышы халык гореф-гадәтләре, йолалары (аеруча туй йолалары), бәйрәмнәр һәм яшьләр уеннары б-н бәйле. Уен («Ай, йолдызым», «Көймә килә, көймә килә» һ.б.) һәм бию («*Әнисә*», «Әпипә», «Бие, бие, Хәйбулла» һ.б.) төрләренә бүленәләр. Уен Т.лары 1930–40 елларда авылларда киң таралган була. Бию Т.лары хәзерге вакытта да бик популяр. Т.ларны Н.С.Исәнбәт, И.Н.Надыйров, Р.Ф.Ягъфәров һ.б. җыя һәм өйрәнә.

*Әд.:* Б ә д и г ы й Х. Халык әдәбияты: Табышмаклар, такмаклар, такмазалар. К., 1913; И с ә н б ә т Н. Балалар фольклоры. К., 1941; Ф ә й з и Җ. Халык җәүһәрләре. К., 1971; Татар халык иҗаты: Йола һәм уен җырлары. К., 1980; Я г ъ ф ә р о в Р. Татар халкының уен фольклоры. К., 2002. *И.Н.Надыйров.*

**ТАКМАКЛА́П ЕЛА́У**, фольклор жанры. Татар такмаклап елавының (елау-сыктау), гадәттә, кайбер вариацияләр б-н тотрыклы поэтик тексты бар; сиргәгрәк — импровизацияләнгән поэтик әсәр. Иң күпсанлы төркемне туй Т.е.лары тәшкил итә, аларда кияүгә биреләсе кыз туган йортыннан аерылу сагышын белдерә. Туй Т.е.лары мишәрләрдә («Кычкырыгыз миңа: «Таң кучат»; «Китәмен лә инде, китәмен»), керәшеннәрдә («Тудыкайлар») бик аһәңле һәм тирән эмоциональ көчкә ия. Татарларда җеназа сыктаулары юк дигән фикер татар фольклористикасында озак яши.

Ф.С.Баязитованың 1980–90 еллардагы экспедицияләре аларның Себер һәм Әстерхан татарларында, татарлашкан мордваларда барлыгын ачыклый. Кайвакыт Т.е.ларның эчтәлеге ислам рухы б-н сугарылган (үлгән кешегә Аллаһның рәхмәте яусын, урыны оҗмахта булсын дип теләүләр); аларның кайберләре төнгә укыла торган мөселман догалары б-н тәңгәл килә.

*Әд.:* М ө х ә м м ә т җ а н о в Р. Туй йола поэзиясе // Татар әдәбияты мәсьәләләре. Уфа, 1972; Татар халык иҗаты: Йола һәм уен җырлары. К., 1980; М ә һ д и е в М.С. Йола фольклоры // Фольклор жанрларын система итеп тикшерү. К., 1987; Б а я з и т о в а Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. К., 1995; У р м а н ч е Ф. Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә. К., 1997; Казанская история. М.–Л., 1951.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ТАКОВА́Р** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 33 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ульянов өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 235 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1720 еллардан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–1860 та Удел ведомствосы карамагында; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да чиркәү-приход мәктәбе, 4 сәүдә-сәнәгать йорты була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 566,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 187, 1897 дә — 494, 1913 тә — 591, 1920 дә — 646, 1926 да — 687, 1938 дә — 769, 1949 да — 665, 1958 дә — 716, 1970 тә — 622, 1979 да — 590, 1989 да — 311, 2002 дә — 293 кеше.

**ТАКСИ́**, к. *Шәһәр транспорты.*

**ТАКТАЛАЧЫ́К** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 14 *км* көнбатыштарак, Шәбез елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 832 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1702 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Такталачык, Иске Такталачык исемнәре б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышында* Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында Т.та волость идарәсе, полиция урядниги фатиры урнаша; 2 мәчет, мәктәп, мәдрәсә, земство хастаханәсе, 8 җил тегермәне, бакалея, ашлык саклау-сату кибетләре эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 13644 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Уфа губернасының Минзәлә өязе Шәрип (Такталачык) волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1747 дә — 27 ир-ат (типтәрләр), 1795 тә — 422, 1834 тә — 792 (асабалар); 1859 да — 1507, 1870 тә — 1545, 1884 тә — 1805, 1897 дә — 1996, 1906 да — 2473, 1920 дә — 2115, 1926 да — 2272, 1938 дә — 1781, 1958 дә — 1153, 1970 тә — 1256, 1979 да — 1164, 1989 да — 1000, 2002 дә — 828 кеше.

**ТАКТАЛАЧЫ́К КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Актаныш р-нының Такталачык һәм Уразай авыллары янында урнашкан. Т.к. истәлекләре 1956 елда А.П.Шокуров, 1958 дә В.Ф.Генинг, 1960–70 елларда Е.П.Казаков һ.б. тарафыннан тикшерелә. Т.к. терр-ясендә 350 дән артык кабер өйрәнелә, ш.и. 5 кабер — Буралы курган, 70 — Чиркәскүл, 11 — Кушнаренко, 274 — Чиялек археол. культураларына нисбәтле. *Буралы курган культурасына* караган каберлекләрдә бөгәрләнеп яткан кеше сөякләре баш ягы б-н төньякка юнәлтелгән; балчык савытлар табыла. *Чиркәскүл культурасы* каберләрендә гәүдә сөякләре бераз бөгәрләнгән, баш ягы б-н көнчыгышка каратылган; әйберләр комплексын измәсенә кабырчык кушылган балчык савытлар, бронза пычаклар, чакматаш ук очлыклары һ.б. тәшкил итә (материаллар б.э.к. 2 меңьеллыкның 3 нче чирегенә б-н билгеләнә). *Кушнаренко*



Такталачык каберлегеннән көмеш чылбыр.

*культурасына* нисбәтле каберлекләрдә җирләнгәннәре (баш сөяген ясалма үзгәртү күзәтелә) төньякка юнәлтелгәннәр; әвәләп ясалган балчык савытлар, сугыш кораллары, ат дирбияләре, бизәнү әйберләре һ.б. (7 йөз) табылган. *Чиялек культурасына* караган каберлекләр мөселман йолалары буенча башкарылган; кайберләрендә, барыннан да элек балалар каберләрендә, мәҗүсилек билгеләре күзәтелә; әвәләп ясалган, тараксыман-баусыман бизәкләр төшерелгән йомры төпле савытлар, мәет битлеге калдыклары, Алтын Урда тәңкәләре (14 йөз) барлыгы ачыклана.

*Әд.:* Ш о к у р о в А.П. Материалы к археологической карте нижнего течения р.Белой и среднего течения р.Ик // Древности Башкирии. М., 1970; К а з а к о в Е.П. Памятники болгарского времени в восточных районах Татарии. М., 1978; ш у л у к. Памятники черкаскульской культуры в восточных районах Татарии // Советская археология. 1979. № 1; ш у л у к. Кушнаренковские памятники Нижнего Прикамья // Об исторических памятниках по долинам Камы и Белой. К., 1981; Археологические памятники Восточного Закамья. К., 1989.

*Е.П.Казаков.*

**ТАКТАЛЫ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Наясолка елгасының (Бизнә, Кама елгалары бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 13,5 *км*. Бассейнының мәйданы 57,7 *км*². Идел аръягы түбәнлеге буйлап ага. Елга башы Әлки р-ны Иске Такталы авылыннан 2 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Спас р-ны Татар Такталысы авылыннан 2 *км* төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 136 *м*,

тамагыныкы — 78 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,23 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Җәен озак вакыт яңгырлар яумаганда елга урыны-урыны б-н кибә һәм суы тамагына кадәр барып җитми. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 97 *мм*, ташу агымы катламы 92 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Суы язын каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

**ТАКТАЛЫ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 20 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 335 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новопоселённая (Новая) Тохтала исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәктәп, 4 тегермән, 4 ярма яргыч, 1 тукыма һәм 8 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2506 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәм волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан — Алексеев, 1977 нең 29 августыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 125 ир-ат; 1859 да — 913, 1897 дә — 1578, 1908 дә — 1896, 1920 дә — 1964, 1926 да — 1291, 1938 дә — 922, 1949 да — 903, 1958 дә — 744, 1970 тә — 697, 1979 да — 621, 1989 да — 337, 2002 дә — 375 кеше.

**ТАКТА́Ш** Рафаил Һади улы (26.1.1926, Казан — 14.2.2008, Ташкент), сәнгать белгече, рәссам, сәнгать фәннәре д-ры (1974), Үзбәкстан ССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1978). Үзбәкстан САнең шәрәфле әгъзасы (1998). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1959). Һ.*Такташның* улы. 1945–50 елларда В.И.Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тының нәкышь бүлегендә укый (П.Д.Покаржевский остаханәсе). И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тының сәнгать теориясе һәм тарихы ф-тын тәмамлый (1954). 1961 дән Ташкентта Хәмзә исем. Сәнгать белеме фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, проф. (1994 тән). Т. Үзбәкстан проф. рәссамнарының хәзерге заман сынлы сәнгатен һәм иҗатын тикшерә. «Үзбәкстанның сынлы сәнгате: XIX йөзнең икенче яртысы — XX йөзнең алтмышынчы еллары» («Изобразительное искусство Узбекистана: вторая половина XIX в. — шестидесятые годы XX в.», Таш., 1972), «Үзбәкстанның хәзерге заман графикасы» («Современная графика Узбекистана», Таш., 1973), «Сәнгати-тәнкыйди этюдлар (үзбәк совет сынлы сәнгатенең үсеш юллары һәм проблемалары)» («Художественно-критические этюды (пути и проблемы становления узбекского советского изобразительного искусства», Таш., 1992) монографияләре; рәссамнар иҗатына багышланган китаплар һәм альбомнар: «Бахром Хамдами» (Таш., 1969), «Урал Тансыкбаев» (Таш., 1978), «Н.В.Кашина, 1896–1977: Тормышы һәм иҗаты» («Н.В.Кашина, 1896–1977: Жизнь и творчество»), «Александр Волков = Alexander Volkov» (икесе дә — Таш., 1982), «Фарук Каһаров» (М., 1985), «Жолдасбек Куттымуратов = Zholdasbek Kuttmuradov» (Таш., 1985) авторы.



Р.Һ. Т а к т а ш. «Энем Аван Такташ портреты». Кәгазь. Карандаш. 1956.


Жанрлы картиналар, портретлар, пейзажлар («Әндиҗан янындагы саил», 1948; «Хәмзәабад кызы», «Үлмәсхон портреты», «Хумсан. Кичкырын»; барысы да — 1950 еллар һ.б.), акварельләр, карандаш рәсемнәре авторы. Т. әсәрләренең шәхси күргәзмәсе 2006 да Ташкентта уздырыла. Әсәрләре А.А.Бахрушин исем. Үзәк театр музеенда (Мәскәү), Дәүләт әдәбият музее (Мәскәү), Үзбәкстан Дәүләт әдәбият музее (Ташкент), И.В.Савицкий исем. Дәүләт сәнгать музее (Нөкес ш., Үзбәкстан), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее, ТР Милли музеенда саклана. Үзбәкстан Респ-касының «Дустлик», «Эл-юрт хурмати» орденнары, Үзбәкстан САнең алтын медале б-н бүләкләнә.



Р.Һ. Т а к т а ш. «Әндиҗан янындагы саил». Киндер. Майлы буяу. 1948.



Р.Һ. Такташ.



Һ.Х. Такташ.

Х е з м.: О себе и об искусстве // San'at. 2006. № 1.

*Әд.:* Г а б д у л л и н А. Рафаил Такташ // Мирас. 2009. № 12.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ТАКТА́Ш** Рәмзия Һидиәтулла кызы (7.2.1932, Казан), әдәбиятчы, тәрҗемәче, музыка һәм театр сәнгатен пропагандалаучы, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1988). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), Казанның 117 нче мәктәбендә рус теле укыта. 1963 елдан Татар опера һәм балет театрының әдәбият бүлеге мөдире, 1989 дан театрдагы музей фондларының өлкән саклаучысы; бер үк вакытта, 1972–76 да, Казан ун-тында укыта. Р.Яхинның «Фидаи» балеты либреттосы (1987), радио һәм телевидение тапшырулары сценарийлары авторы. 1956 дан Г.Тукай, М.Әмир, Г.Әпсәләмов, А.Гыйләҗев, Ш.Маннур, Ф.Хөсни, А.Шамов һ.б.ның чәчмә әсәрләрен, ш.у. татар халык әкиятләрен татарчадан русчага тәрҗемә итү б-н шөгыльләнә. Т.Миңнуллин, Х.Вахит, Р.Батулла пьесаларын рус теленә синхрон тәрҗемә итүче (татар театрлары спектакльләре вакытында файдаланыла). Опера яратучылар клубы б-н җитәкчелек итә, тамашачылар өчен конференцияләр, иҗат кичәләре, сәхнә ветераннары хөрмәтенә хәйрия акцияләре уздыра.


Х е з м.: Народные артисты. К., 2011 (автордаш).

**ТАКТА́Ш** (Такташев) Һади (Мөхәммәтһади) Хәйрулла улы (1.1.1901, Тамбов губ., Спас өязе Сыркыды а. — 8.12.1931, Казан), шагыйрь, хәзерге татар поэзиясенә нигез салучыларның берсе. Авыл мәдрәсәсендә белем ала. Гаиләнең матди хәле авыр булу сәбәпле, 1915 елда Бохарага китә. 1917 дә «Яшь бохарачылар» җәдитчеләр оешмасы әгъзасы, хәйрия фондында эшли. 1918 дә «Олуг Төркестан» г-тасында шагыйрьнең «Төркестан сахраларында» исемле беренче шигыре һәм «Яшь бохарачылар» эшчәнлеге турындагы мәкаләсе басыла. Оешма тар-мар ителгәннән соң, 1918 дә Т. туган авылына кайта, укытучы булып эшли. 1919 да Оренбургка китә, «Хөсәения» мәдрәсәсе каршында ачылган Татар халык мәгарифе ин-тына укырга керә, «*Юксыллар*

*сүзе»* г-тасының җаваплы сәркәтибе булып эшли, шунда шигырьләрен бастыра.

1921–22 дә Ташкентта яши, Төркестан эшче-диһкан коммунистлар ун-тында укыта, күп яза. 1922 нең җәен Мәскәүдә уздыра, әдәби кичәләргә йөри, В.Маяковский, С.Есенин һ.б. рус шагыйрьләренең чыгышларын тыңлый. Казанга кайта, Беренче үрнәк татар театрында суфлёр, соңыннан «Чаян» (1923–24, 1929–31), «Октябрь яшьләре» (1925), «Авыл яшьләре» (1926), «Азат хатын» (1926–29) ж-ллары редакцияләрендә эшли. 1922 дә Үрнәк театр сәхнәсендә Т.ның «Җир уллары» пьесасы сәхнәләштерелә; Идея ролен шагыйрь үзе башкара. 1923 тә Т.ның «Җир уллары трагедиясе һәм башка шигырьләр» исемле беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә, һәм шуның б-н шагыйрь иҗатының романтик чоры тәмамлана. Бу чор әсәрләренә («Күктән сөрелгәннәр», 1918; «Үтерелгән пәйгамбәр», 1918 һ.б.) хыялны чынбарлыкка, яхшылыкны яманлыкка, гадәтине илаһилыкка, үзенең «мин»ен әйләнә-тирә дөньяга каршы кую хас. Чор һәм милли яшәеш тарафыннан күтәрелгән социаль, әхлакый, сәнгати мәсьәләләрне үзенчә хәл итәргә тырышып, ул Байрон, Гёте, А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, В.Маяковский, С.Есенин, Г.Тукай, С.Рәмиев идеяләрен һәм темаларын үстерә.

Шагыйрьнең бу чор иҗатына *гыйсъянчылык* һәм Аллаһка каршы чыгу мотивлары хас. Т. — тормыш «чүлендә» каңгырып йөрүче ялгыз гыйсъянчы; гармония иле, хәнҗәр (чистарыну, сафлану), сандугач (шигъри иҗат), «урман кызы» (хыял) һ.б. фольклор образларын һәм суфичылык символларын актив куллана. Беренче бөтендөнья сугышы, 1921–22 дәге ачлык, татар сәясәт эшлеклеләренә каршы алып барылган репрессияләр (к. «*Солтангалиевчелек*»), күмәкләштерү процессы аның иҗатында тирән эз калдыра («Ачлык патша», 1920; «Нәләт», 1922; «Күләгәләр», 1922; «Син дошманым минем», 1929). «Җир уллары трагедиясе»ндә (1923) Т., әхлакый һәм рухи кыйбласын югалтып, ата-бабаларның гореф-гадәтләренә, Аллаһка хыянәт итеп, золым хакимлегенә буйсынган хәзерге заман кешесенең фаҗигасен тасвирлый. Шагыйрь Окт. рев-циясенең гуманистик идеяләре тискәре борылыш алуны, рев-ция юлбашчыларының замандашларын киләчәккә «канлы кырлар» аша алып баруларын күрә. «Җир уллары трагедиясе»нең кереш сүзендә Т. үзенең шигырь төзелешенең элеккеге рәвешеннән китәчәген әйтә («Бакырганидан алып Тукай аркылы хәзергә кадәр биш йөзләрчә шагыйрьләр тарафыннан сузылып килгән татарның иске шигъри өслүбе җимерелергә тиешле») һәм көйләп укуга түгел, ә халыкчан такмак шигыре һәм җанлы сөйләм интонациясенә нигезләнгән яңа шигырь төзелешен, яңа ритмика үрнәкләрен тәкъдим итә. Аның шигырьләрендә алгы планга шәхес образы чыга башлый, ул шигърияттне индивидуаль интонация һәм сурәтләү чаралары б-н баета. Т. татар поэзиясендә беренчеләрдән булып лиро-эпик әсәрләрдә тоташ фабула һәм эзлекле сюжеттан котыла. Аның поэмаларында традицион төенләнеш, вакыйгалар



Султан уңга: М.Гафури, Һ.Такташ, Г.Камал. 1929.

үстерелеше, чишелеш тә юк. Әсәр эчтәлеген оештыручы һәм төзүче рефреннар зур роль уйный. Т. иҗатына бер үк мотивлар хас: таң, нур, гармония, бакча. Бер үк образлар бик күп әсәрләрендә төрлеләндерелә яки кабатлана. «Гыйсъян» (1923), «Казан» (1923), «Пасха чаңнары» (1923) шигырьләрендә Казанның нәп чорын күз алдына китереп бастыра. Ул күңеле бизүен яшерә алмый; комсызлык, икейөзлелек аның тәнкыйть объектына әверелә. 1923 ел Т. иҗатында борылыш елы була. Аның «Такташ үлде» (1923) шигыре шагыйрьнең кискен кризис кичерүен чагылдыра, анда ул үзенең үткәненнән баш тартуын белдерә. Шагыйрь реализмга юл тота. Т. чор таләбенә буйсынып яза башлый. «Гыйсъян», «Октябрь төне» (1923) шигырьләрендә замандашның тынгысыз рухы матурлыгына дан җырлый.

Гомеренең Казан чоры башында чын матурлык Т. күзаллавында көрәш идеясе б-н, соңрак мәңгелек кыйммәтләр дөньясы б-н аерылгысыз бәйле була. Әсәрләренең революцион пафосы аша татар халкына хас лиризм һәм уйчанлык күзәтелә: «Зәңгәр күзләр» (1923), «Нәни разбойник» (1926), «Болай... гади җыр гына» (1928), «Үтеп барышлый» (1928), «Ак чәчәкләр» (1929). Ватан темасы үсеш ала: «Сыркыды авылы» (1924), «Әйдә, энем!» (1926) һ.б. Башлангыч чор мәхәббәт лирикасында сөйгән яр образы хыял, символ рәвешендә тасвирланса: «Таң кызы» (1921), «Урман кызы» (1922), соңрак ул образ төгәлрәк төс ала: «Ләйлә» (1927), «Алсу» (1929). Т.ның танылган әсәрләреннән берсе — «Мәхәббәт тәүбәсе» (1927). Анда, «Югалган матурлык» (1929) пьесасындагы кебек, шагыйрь чор йогынтысына каршы чыгып, бөек әхлакый принципларны раслый:

...Ана!
Бөек исем,
Нәрсә җитә ана булуга!
Хатыннарның бөтен матурлыгы,
Бөтен күрке ана булуда...

Сәяси асыллы «Давылдан соң» (1924), «Сыркыды авылы» (1924), «Никахсызлар» (1925) шигырьләре чорның социаль заказын чагылдыра, аларда соц. реализмның үзенчәлеге ачык күренә. Аерым бер төркемне «газета» шигырьләре тәшкил итә: «Лорд Чемберленга СССР крәстияне Һади Такташтан җавап нотасы» (1927), «Мулла Чемберлен» (1929) һ.б. 1929 да М.Максудка язылган хатында: «...ул нәрсәләремдә идеологический як шәп булыр. Художество ягы гына әйбәт булмас», — дип яза. Татар акад. театры сәхнәсендә аның «Күмелгән кораллар» (1927), «Югалган матурлык» (1929), «Камил» (1930) пьесалары сәхнәләштерелә. 1924 тә язылган «Гасырлар һәм минутлар» поэмасында шул чорның төп герое итеп В.И.Ленин тасвирлана. Шагыйрьнең поэмада чагылган якты киләчәккә булган өметләре тирән уйланулар һәм яшерен канәгатьсезлек б-н алышына: «Киләчәккә хатлар» (1931) поэмасы, «Камил» пьесасы. 20 йөзнең канлы асылын аңлап, Т. илгә янаган фаҗигане сизә. Совет режимының тоталитар идеологиясен кабул итмичә, ул илдәге берпартиялелек шартларында барлыкка килгән чынбарлык кысаларына сыеша алмый башлый. Нәтиҗәдә, шагыйрь өстеннән әдәби мәхкәмәләр оештырыла, аның әсәрләре басылмый башлый, ул матди кыенлыклар кичерә, чыгышы б-н кулак булуда гаепләнә һ.б.

Т.ның беренче шигъри җыентыгы чыгуга, аның исеменә игътибар юнәлтелә: аны я эчкерсез яраталар һәм ихтирам итәләр, я сөймиләр һәм яла ягалар. Үзе исән чакта аны я «вак буржуаз индивидуалист», я «юлдаш» дип, үлеменнән соң пролетар рев-циягә өндәүче, радикаль-гражданлык поэзиясен тудыручы дип атыйлар. Ул проза һәм кинодраматургия өлкәсендә эшли. Балалар өчен дә хикәяләр яза (иң танылганнары арасында — «Караборынның дусты», 1927). Матбугат битләрендә публицистик мәкаләләр, очерклар, фельетоннар бастыра. Ш.у.к. *Гыйсъянчылык*.


Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 4 томда. К., 1947–63; Әсәрләр: 3 томда. К., 1980–83; Стихотворения и поэмы. М., 1955; Письма в грядущее. К., 1971.

*Әд.:* Х ә й р и Х. Һади Такташ. К., 1949; Г о с м а н Х. Такташ поэзиясе. К., 1953; Н и г ъ м ә т и Г. Сайланма әсәрләр. К., 1958; Г а л и у л л и н Т. Егерменче еллар татар шигърияте // Мирас. 1997. № 5; Х а л и т Г. Поэзия дерзаний. К., 1980; Х а б у т д и н о в а М.М. Проблема личности в творчестве Х.Такташа: Автореф. дис... К., 1998. *М.М.Хәбетдинова.*

**ТАКТА́ШЕВ** Шамил Габделхәмит улы (19.1.1949, Әстерхан ш. — 5.09.2011, шунда ук), нәкышьче, график. В.И.Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тын тәмамлый (1974), А.М.Грицай һәм Д.Д.Жилинский шәкерте. 1974–93 елларда РСФСР Сәнгать фондының Әстерхан сәнгать-сәнәгать остаханәләре рәссамы, 1980 нән П.А.Власов исем. Әстерхан сәнгать уч-щесендә, 2001 дән — Әстерхан төзүче инженерлар ин-тында, 2008–09 да Әстерхан ун-тында укыта. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1980).

Т.ның таланты, Әстерхан төбәгенең әйдәп баручы нәкышьчеләренең берсе буларак, сюжетлы-тематик картиналар жанрында ачыла. Рәссам майлы буяу, якты, ачык темпера һәм катнаш техникада башкарган үзенчәлекле стильле картиналарында кешенең рухи эзләнүләрен, актуаль социаль темаларны философларча ачкан символик-аллегорик һәм метафорик образлар иҗат итә. Аның күп кенә картиналары серияләргә тупланган: «Гармония химерасы», «Почмак», «Строфа», «Антик мотивлар», «Күчеш чоры», «Сәбәп» (барысы да — 1990 елларның 2 нче яртысы — 2000 ел-

лар). Т. үзенең иҗатында совет нәкышь мәктәбенә хас картиналардан («Бакчада», 1977; «Без» триптихы, 1987–90; «Җиңү», 1987; «Саф», 1988; «Яз», 1990), образлы-символик һәм формаль стильле («Бер үк вакытта», 1991; «Җир ачыла», 1992; «Тәүлек», 1994; «Грим», 1995; «Дафна», «Курчак», «Бары шул гына», барысы да — 1997; «Болыт», «Үзем каршында», «Таң кызы Эос», барысы




Ш.Г. Т а к т а ш е в. «Бакчада». 1977. П.М. Догадин исем. Әстерхан картиналар галереясы.

да — 1998; «Роза», 1999) һәм табигый визуаль ракурслы акад. нәкышь әсәрләренә («Фәрештә», 2000; «Рәссам һәм модель», 2001; «Капитель», 2002; «Аллея», 2003; «Фәрештә сурәте», «Минем хакта», икесе дә — 2004; «Киемнәр һәм кораллар», 2007; «Орнамент», 2008; «Савыт», «Кош», икесе дә — 2008; «Хыялый күренешләр», 2009 һ.б.) күчә бара.

Т.ның гаҗәеп таланты станлы графикада да үсеш ала (карандаш, тушь, гуашь, пастель, акварель: А.Дантенең «Илаһи комедия»се темасына рәсемнәр сериясе, 1988–89; «Чакыручы», 1995; «Билге», «Кентавр», «Рәсем ясаучы», барысы да — 1998; «Шкатулка», 2001; «Рәнҗетелгән фәрештә», 2005; «Җил», 2006; «Иртәнге аш», 2007; «Очрашу», «Сатып алучы», «Ай», барысы да — 2008).

Зона — «Зур Идел» (Горький ш., 1974; Казан, 1991, 1998; Түбән Новгород, 1998); бөтенроссия — В.Хлебниковка багышланган күргәзмә-чыгышлар (Әстерхан өлкәсе Кече Дәрбәт а., 1990); бөтенсоюз — сәнгать югары уку йортларын тәмамлаучылар күргәзмәсендә («Әбием һәм мин» диплом эше куела; Мәскәү, 1977); заманча «Чагылыш» тәҗрибә сәнгате (Элиста ш., 1991), «Арт-коллегия»



Ш.Г. Т а к т а ш е в. «Ядкәр». 2000.

(С.-Петербург, 1994); чит ил — «Хәзерге заман Россия нәкыше» (Джакарта, Индонезия, 2003); бөтентатар — «Татарт» (С.-Петербург–Казан, 1991), С.-Петербург татар милли-мәдәни автономиясе рәссамнарының «Рәссамнар — шагыйрьләргә» (2006) күргәзмәләрендә катнаша.

Шәхси күргәзмәләре Әстерханда (1984, 1987, 1989, 1993, 1996, 1998, 1999, 2008, 2009) һәм С.-Петербургта (1994) уза. Әсәрләре П.М.Догадин исем. Әстерхан картиналар галереясында, Россиядә һәм чит илләрдәге шәхси тупланмаларда саклана.

Т. — публицистик мәкаләләр, «Колода» китабы (1999) авторы. 2001 елда Т.Соколова шушы китап нигезендә Т. б-н берлектә шул исемдәге кинофильм иҗат итә. Сынлы сәнгать өлкәсендә губернаторның Б.М.Кустодиев исем. бүләгенең беренче лауреаты (Әстерхан ш., 2000).

*Әд.:* Такташев. Выставка живописных произведений: Буклет. Астрахань, 1998; Такташев. Пересуды. Живопись в среде прочего: Буклет. Астрахань, 1999; И з м а й л о в Д. Шамиль Такташев: Творческий путь художника // Идель. 1999. № 2; К а р а е в а Л.М. Астраханский союз художников за 70 лет. Астрахань, 2008.

**ТАКЫЯ́ УТЫ́** (Selinum), чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 4 төре билгеле, Европа, Азия һәм Төньяк Америкада таралганнар. ТР да бер төре — әнеч яфраклы Т.у. (S. carvifolia) бар, респ-каның бөтен терр-ясендә очрый. Дымлы урыннарда, куаклыкларда үсә. 30–100 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы тирән буразналы, кабыргалары канатлы. Яфраклары икешәр, өчәр каурыйсыман, каурыйсыман озынча бүленмә яфракчыклы. Чәчәкләре ак яки алсу, катлаулы чатырга җыйналган. Җимеше — салынкы җимешлек. Июль–августта чәчәк ата. Сентябрьдә җимеш бирә. Җимешләрендә эфир мае, кумарин, майлар бар; антибактериаль үзлеккә ия. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ТАЛ** (Salix), талчалар семьялыгыннан яфрак коючан агач, куак яки куакчыклар. 600 дән артык төре билгеле, күбесенчә Евразия һәм Төньяк Американың салкын һәм уртача поясларында очрый. ТР терр-ясендә 18 төре бар, ак Т. (S. alba), мурт Т. яки ракита (S. fragilis), кәҗә Т.ы яки бредина (S. caprea), очлы яфраклы Т. яки верба (S. acutifolia), чыбык Т. (S. viminalis) һ.б. киң таралган. Таллыклар барлыкка китереп, елга тугайларында һ.б. сулык ярларында, уйсулыкларда, ерымнарда үсәләр. 0,2–25 *м* биеклектәге агачлар яки куаклар. Яфраклары чиратлашкан, күпчелеге ланцетсыман, түгәрәктән тар кыякка кадәр, каурыйсыман сеңерле. Чәчәкләре берле чәчәк төркеменә — ата һәм ана алкаларга җыйналган, кайбер төрләрдә алар яфрак ярганчы күренә. Җимеше — очкалак озын төкчәле күп орлыклы тартмачык. Апрель–майда чәчәк ата. Җимешләре, чәчәк атып бетергәннән соң, 3–4 атнадан өлгерә. Орлыктан, ботактан, төп үсентеләреннән үрчи. Туфракка талымсыз. Кайрысында гликозид һәм дуплау матдәләре бар; аннан ясалган препаратлар эренле шеш һәм җәрәхәтләрне дәвалау өчен, тән кызышканда һәм бө-



Тал.

рештергеч чара буларак кулланыла. Үзагачын — төрле эшләнмәләр, сыгылмалы нәзек чыбыкларын — кәрзин, йорт җиһазлары һ.б. әйберләр ясауда файдаланалар. Кара Т. (S. pentandra), розмарин яфраклы Т. (S. rosmarinifolia), кара җиләксыман Т. (S. murtilloides) һ.б. яшелләндерүдә файдаланыла. Очлы яфраклы Т., ак Т., кәҗә Т.ы һ.б. төрләре ерым һәм текә ярларны ныгытуда кулланыла. Баллы үсемлек. Лапландия Т.ы (S. lapponum), розмарин яфраклы Т., кара җиләксыман Т. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ТАЛА́К ҮЛӘНЕ́** (Chrysosplenium), ташкуранчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 55 тән артык төре билгеле, ике ярымшарның да тропиктан тыш өлкәләрендә таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — алмаш яфраклы Т.ү. (C. alternifolium), ара-тирә барлык районнарда да очрый. Дымлы, күләгәле урманнарда, куаклар арасында, урман инешләре буенда үсә. 5–15 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы нәзек, шуышма. Сабагы туры. Яфраклары ачык яшел, чиратлашкан, түгәрәк-бөресыман, сирәк төкчәләр б-н капланган. Чәчәкләре вак, алтынсу-сары төстә, сабак очындагы калкан чәчәк төркемендә. Җимеше — күп орлыклы тартмачык. Апрель–майда чәчәк ата. Җимешләре июньдә өлгерә. Вегетатив юл б-н (столоннардан) үрчи. Халык медицинасында төнәтмәсе йөткерү, талак авырулары вакытында, җәрәхәтләрне төзәтү чарасы буларак кулланыла.

**ТАЛАКДА́Р**, ж и д е г ә н у т ы (Trientalis), нәүрүзгөлчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 3–4 төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача һәм салкын поясларында таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — Европа Т.ы (T. europaea) Кама алдында очрый. Нигездә, ылыслы урманнарда, ш.у. куаклыкларда, кисентеләрдә, сфагнум мүкле сазлыкларда үсә. 5–15 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы нәзек, шуышма. Сабагы туры. Яфраклары чиратлашкан, кире-озынча түгәрәк яки ланцетсыман, сабакның түбәнге өлешендә ваграк. Чәчәкләре ак яки алсу төстә, озын нәзек чәчәк сапларында, өске яфрак куентыгында берәрләп урнашкан. Җи-

меше — шарсыман тартмачык. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре җәй ахырында өлгерә. Вегетатив юл б-н (столон очында урнашкан бүлбеләрдән яңа үсемлекләр бирә) үрчи. Составында сапонин, витаминнар бар. Халык медицинасында Т. төнәтмәсе яра төзәтү һәм ялкынсынуга каршы чара буларак кулланыла.

**ТАЛА́Н** Мария Вячеславовна (15.7.1964, Казан), хокук белгече, юридик фән. д-ры (2002), проф. (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1986), шунда ук эшли, 1989 елдан җинаять хокукы кафедрасында, бер үк вакытта, 2003–11 дә, юридик ф-т деканы урынбасары. 2011 дән җинаять хокукы каф. мөдире. Хезмәтләре җинаять хокукы мәсьәләләренә, балигъ булмаганнар тарафыннан җинаять кылуларны кисәтү, икътисади эшчәнлек өлкәсендә закон бозулар проблемаларына карый.

Х е з м.: Преступления в сфере экономической деятельности: Вопросы теории и законодательного регулирования. К., 2001; Уголовное право России. Общая часть: Учеб. К., 2003 (автордаш); Уголовно-правовая охрана экономической деятельности. К., 2009.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**ТАЛА́НОВ** Иван Павлович (21.8.1956, Питрәч р-ны Тегермән Тавы а.), галим агроном, а.х. фән. д-ры (2004), проф. (2009), ТРның атказ. агрономы (2006). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1983), Питрәч р-ның Ленин исем. һәм «Совет» к-зларында баш агроном булып эшли. 1989–92 елларда «Татарстан кыры» ФҖБдә фәнни хезмәткәр. 1992 дән Казан аграр ун-тының үсемлекчелек кафедрасында, проф. (2004). 2014 тән агрохимия һәм туфрак белеме каф. мөдире. Хезмәтләре язгы бодай үстерү мәсьәләләренә карый. Т. беренчеләрдән булып ТР өчен бодайның төрле микозларының зарары картограммаларын эшли.

Х е з м.: Оптимизация приёмов формирования яровой пшеницы. К., 2003; Яровая пшеница в лесостепи Поволжья. К., 2005; Практикум по растениеводству: Учеб. пособие. М., 2008.

**ТАЛА́НОВ** Юрий Иванович (20.12.1952, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (2001). 1975 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1975 тән РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2002 дән). Хезмәтләре югары темп-ралы үтә үткәргечләрне тикшерүгә карый. Т. беренче булып үткәрүчәнлек электроннарының спин-рәшәткә релаксациясе туктап калуын экспериментта күзәтә (1985). Спин релаксациясендә лантан-стронций керамикасының үтә үткәрүчән халәткә күчеше б-н бәйле когерентлык эффектын, югары темп-ралы үтә үткәргечләрдә микродулкынлы йотылу барышында магнит агышы сызыкларының күмәк пиннингы эффектын таба. Катламлы үтә үткәргечләрдә магнит үзлекләре һәм элекке хәлнә кайтмау сызыгы гистерезисы механизмнарын, аз энергияле ионлы нурланышның югары темп-ралы үтә үткәрүчән юка элпәләр пиннингына тәэсирен ачыклый. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Прямое наблюдение замораживания спин-решёточной релаксации электронов в малых металлических частицах // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1986. Т. 43, вып. 7 (автордаш); Коллективный характер крипа потока по данным микроволнового поглощения в монокристаллах YBaCuO // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1992. Т. 55, вып. 8 (автордаш); Локальные свойства микроскопического фазового расслоения в монокристаллических плёнках $La_{1-x}Ca_xMnO_3$ по данным электронного спинового резонанса // Журн. эксперим. и теорет. физики. 2007. Т. 132, № 7 (автордаш).

**ТАЛА́НТОВ** Алексей Васильевич (15.9.1924, Казан — 29.8.1987, шунда ук), химик физика өлкәсе белгече, техник фән. д-ры (1962), проф. (1964), ТАССРның һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1972, 1975). 1948 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, очкыч аппарат двигательләре ф-ты проф. (1963 тән), деканы (1962–65), реактив-һава двигательләре каф. мөдире (1979–87). Хезмәтләре агым эчендә турбулент яну процессын өйрәнүгә карый. Т.ның тикшеренү нәтиҗәләре авиация двигательләренең яну камераларын эшләгәндә, нефть бирүчәнлеген арттыру максатында нефть катламнарына җылылык б-н тәэсир иткәндә, атмосферага яну продуктларының агулы матдәләр чыгаруын киметү юлларын эзләгәндә файдаланыла. «Известия вузов. Авиационная техника» ж-лының редакторы була (1965–87). Уйлап табуга 38 авторлык таныклыгы бар. «Просится сердце в полёт» шигырьләр җыентыгы (1998) авторы. «Почёт билгесе» ордены; медальләр, ш.и. СССР ФАнең С.И.Вавилов исем. алтын медале, СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре; ТАССР ЮСның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. «Югары белем бирү отличнигы» билгесенә ия.

Х е з м.: Теория и расчёт прямоточных камер сгорания. М., 1964 (автордаш); Основы теории горения. К., 1975; Горение в потоке. М., 1978; Розжиг битумных пластов камерами сгорания авиационного типа. К., 1982 (автордаш).

*Әд.:* С к в о р ц о в а З. В неустанном горении // Советская Татария. 1982. 19 марта.

**ТАЛА́НТОВ** Всеволод Васильевич (7.8.1929, Зөя р-ны Түбән Ослан а.), эндокринолог, мед. фән. д-ры (1978), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1991), ТАССРның атказ. табибе (1973), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1989). Проф. Ә.Б.*Терегулов* һәм СССР МФА академигы В.Г.Баранов шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), шунда ук, 1 нче госпиталь терапиясе кафедрасында эшли, эндокринология курсы мөдире (1963 елдан), эндокринология кафедрасын оештыручы һәм аның мөдире (1976 дан), проф. (1978). Бер үк вакытта ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка клиник хастаханәсе каршындагы Респ-ка диабетология үзәге директоры (1996 дан), проф.-консультант (2002 дән). 1964–66 да Йәмән Гарәп Респ-касындагы совет табибләре төркеме баш табибе. Хезмәтләре эндемик зобның экологик һәм генетик концепциясен эшләүгә, конституциональ диабетологиягә карый. ТР Табиб-эндокринологлары ассоциациясен нигезләүче һәм аның президенты (1967 дән). РФ Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы эндокринология буенча уку-укыту комиссиясе рәисе (1976–96). ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш эндокринологы (1962–97), баш диабетологы (1997 дән). ТР ФАнең Ә.Б.Терегулов исем. премиясе лауреаты. Медальләр б-н бүләкләнә.



В.В.Талантов.

Х е з м.: Патогенез и лечение инсулиновых липодистрофий // Советская медицина. 1974. № 6; Эндемический зоб: Сущность, экология и генетика в этиологии. Дефиниция // Проблемы эндокринологии. 1989. № 4; Сахарный диабет. К., 1990 (автордаш); Сахарный диабет в Татарстане. К., 2000.

*Әд.:* Талантов Всеволод Васильевич // Академия наук Республики Татарстан. К., 2002.

*В.Ф.Богоявленский.*

**ТАЛА́НЦЕВ** Зиновий Михайлович (30.5.1868, Казан губ., Ядрин өязе Янибәк утары — 9.3.1929, Түбән Новгород ш.), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, эшмәкәр, Ядрин шәһәренең нәселдән килгән мактаулы гражданы. Сәүдәгәр улы. Казандагы Өченче ир балалар гимназиясен тәмамлый (1886). 1886–87 елларда Петров игенчелек һәм урман академиясендә укый (Мәскәү), 1887 дә, студентлар җыенында катнашкан өчен, академиядән чыгарыла һәм Мәскәүдән сөрелә. Укуын Берлин югары игенчелек мәктәбендә (1888–89), аннары Казан ун-ты физика-матем. ф-тының табигыять бүлегендә дәвам итә (1890–93, 1896–98; 1893 тә яшерен түгәрәк б-н элемтәсе өчен куыла). Ядрин шәһәренең, 1909 да Түбән Новгородның 1 нче гильдия сәүдәгәрләреннән исәпләнә. Бертуганнары Николай һәм Михаил Таланцевлар б-н бергә «Бертуган Таланцевлар» сәүдә йорты ача. Таланцевларның аракы, май җитештерү з-длары, пристаньнары, Царевококшайск өязендә берничә тегермәннәре була; алар Сембер һәм Казан губерналарында зур пароход хуҗалары һәм җирбиләүчеләр була. Таланцевларның гомуми милек бәясе 900 мең сум б-н бәяләнә. Ядрингa сөргенгә җибәрелгәннән соң (1887), Т. полициянең яшерен күзәтүендә тора (1903 кә кадәр). 1906 да чуаш телендә берничә брошюра бастыра, «*Хыпар*» г-тасы чыгаруда катнаша. Казан губернасыннан 2 нче Дәүләт Думасы депутаты (1907): трудовиклар фракциясенә (бюро әгъзасы һәм рәис урынбасары), финанс комиссиясе составына керә. Законга каршы эшчәнлектә шикләнелеп һәм сул сәяси оешмаларга теләктәшлек күрсәтүе сәбәпле 4 нче Дума сайлауларына кертелми. Т. һәм аның бертуганнары акчасына Ядринда реаль уч-ще, кыз балалар гимназиясе, хирургия һәм күз авырулары дәваханәләре, ятимнәр һәм картлар йортлары, 10 нан артык авыл мәктәбе төзелә. Түбән Новгород ун-тының оештыручыларның берсе, аның попечительләр советы рәисе була. 1918–21 дә РСФСР Халык хуҗалыгы югары советының Баш май җитештерү ком-тында химия бүлеге мөдире. 1921–29 да Түбән Новгород ун-тының химия ф-ты доценты, терлек һәм үсемлек майлары каф. мөдире. Дәреслекләр, күп кенә фәнни мәкаләләр, уйлап табулар авторы.

Х е з м.: Олифоварение и приготовление сиккативов. М., 1924; Технология жиров и масел: В 2 ч. М., 1925–26.

*Әд.:* У с м а н о в а Д.М. Депутаты от Казанской губернии в Государственной думе. 1906–1917. К., 2006; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

**ТАЛАНЧУ́К** Николай Михайлович (3.8.1936, Украина ССРның Хмельницк өлкәсе, Новая Ушица р-ны Кече Шурка а. — 10.9.1999, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (1985), РМА мөхбир әгъзасы (1996). Иркутск ун-тын тәмамлаганнан соң (1964), Иркутск шәһәрендә 23 нче һөнәри-техник уч-ще директоры, 1974 елдан Иркутск пед. ин-тында пед. кафедрасында. 1976 дан Казанда СССР ПФАнең Урта махсус белем бирү ин-тында лаб. мөдире, проф. (1986). 1980 еллар ахырына кадәр һөнәри-техник уч-щеләрдә тәрбия эше проблемаларын тикшерә. 1990 елларда пед. теориясен эшли.

Х е з м.: Введение в неопедагогику: Пособие для педагогов-новаторов. М., 1991; 100 новых идей в педагогике, связанных с открытием фундаментальных законов системного синергетизма. К., 1993; Начала неофилософии: В 2 ч. К., 1995.

*Әд.:* Памяти Н.М.Таланчука // Профессиональное образование. 2000. № 3; Педагогическое наследие профессора Н.М.Таланчука и современные проблемы социального воспитания: Тез. докл. и выступлений на 3 Всерос. науч.-практ. конф. К., 2003.

**ТАЛА́ПИН** Павел Сергеевич (25.6.1951, Алабуга р-ны Колосовка а.), механизатор, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (2004). Россия агросәнәгать комплексының мактаулы хезмәткәре (2011). Алабуга авыл һөнәри-техник уч-щесен тәмамлаганнан соң (1968), Алабуга р-нында: тракторчы, механик (1973–81), баш инженер (1985 елдан), партком секретаре (1987 дән), «Танайка» с-зының бүлек идарәчесе (1988 дән), «Колос» а.х. җитештерү кооперативы рәисе (1996 дан). 1981–85 елларда Танай авыл советы башкарма ком-ты рәисе. Дәүләт бүләге ТРда игенчелектә биол. факторлар нигезендә бөртекле ашлык җитештерүгә ресурс саклау технологияләрен эшләүдә һәм гамәлгә куюда катнашканы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**ТАЛВИ́Р** (тәхәллүсе, чын фамилиясе Башкиров) Алексей Филиппович (21.3.1909, Сембер губ., Буа өязе Батыр а. — 9.9.1979, Чабаксар ш.), чуаш язучысы. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1934). 1928 елдан СССР халыкларының Үзәк нәшриятында чуаш секциясен җитәкли. 1937–39 да «Гудок» г-тасында, 1940–41 дә ВЛКСМ ҮКның пропаганда һәм агитация бүлегендә матбугат инструкторы. 1945 тән Чабаксарда «Коммунизм ялаве» г-тасында хәбәрче, 1949 дан Чуаш АССРның Язучылар берлегендә әдәби консультант, 1954 тән идарә рәисе. 1960 тан Казанда яши, ТАССР Язучылар берлегендә чуаш язучылары секциясе б-н җитәкчелек итә. «Нигез» («Никес», Чабаксар, 1964; рус теленә тәрҗемәсе «Вутлан зажигает огни», М., 1967) романы, «Батыр-ял кешеләре» («Люди из Батыр-яла», М., 1933), «Буа трактында» («Пава суле синче», Чабаксар, 1954), «Барыннан да кыйммәтрәк» («Дороже всего», Чабаксар, 1965), «Идел җиле» («Ветер с Волги», Чабаксар, 1972) повестьлары авторы. Т. китаплары рус, украин, белорус, литва, грузин, молдован, татар, удмурт, болгар телләренә тәрҗемә ителгән. 1970 тән Чабаксарда яши. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ю р ь е в М.И., Р о м а н о в а З.В. Писатели Советской Чувашии: Биобиблиогр. справ. Чебоксары, 1988.

**«ТАЛИ́»**, татар халкының качкыннар турындагы тарихи җыры. Җыр исеменең «Тали җырлары», «Качкынның михнәте бигрәк зур» вариантлары бар. Татар-мишәрләр арасында киң таралган. Авторы — Түбән Новгород губернасының Актук авылыннан Тали кушаматлы Фәйзулла Сәйфетдинов. Җырда ул тормышының чын фактлары турында сөйли. Талины алдалап авыл мулласы Миҗан урынына патша гаскәренә алалар. Әмма ул, аннан качып, туган авылына кайта, тотыла, Себергә сөрелә, аннан ш.у. кача. 25 елдан Тали туган ягына кайта, әмма аны кабат тоталар, яңадан Себергә җибәрәләр.

Җыр текстын 1940 елда Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь р-ны Актук авылыннан Х.Абдуллин язып ала. Беренче тапкыр 1941 нең 12 гыйнварында Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь р-ны «Октябрь коммунасы» г-тасында «Тали беглый бәете» исеме б-н басыла. Җырның 1950–60 елларда Горький өлкәсендә язып алынган тагын 4 варианты бар (кульязмалар ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының фольклор фондында фольклорчы И.Н.Надыйровның шәхси архивында саклана).

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. К., 1988; У р м а н ч е Ф. Тарихи җырлар // Татар халык иҗаты: Дәреслек. К., 2005.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ТАЛИ́Б БИНЕ́ ӘХМӘ́Д** (940–960 еллар), Суар бәклеге идарәчесе. Исеме Суар шәһәрендә 942–960 елларда сугылган акчалардан мәгълүм. Болгар шәһәре идарәчесенә бәйле булмаган беренче тулы хокуклы Суар әмире.

*Әд.:* Я н и н а С.А. Новые данные о монетном чекане Волжской Болгарии в X в. // Материалы и исслед. археологии СССР. 1962. Вып. 111.

**ТАЛИ́ПОВ** Айрат Нурислам улы (11.3.1949, Баулы р-ны Татар Кондызы а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1994). БАССР пед. ин-тын тәмамлый (1974). Каразирек сигезьеллык мәктәбендә (1966 елдан), Татар Кандызы урта мәктәбендә (1968 дән) хезмәт укытучысы булып эшли. Баулы р-нының «Южный» с-зында прораб (1975 тән), партком секретаре (1976 дан), «Байкал» к-зы рәисе (1984 тән), Ютазы р-нының а.х. һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (1995 тән), Бөгелмә р-ны хакимияте башлыгының а.х. буенча 1 нче урынбасары (2001), Ютазы р-нының «Аккош» фермер хуҗалыгы җитәкчесе (2001 дән), «Алтын башак» идарәче компаниясенең ген. директор урынбасары (2004 тән). 2006 дан «Ак Барс» холдинг компаниясе» АҖнең агросәнәгать комплексы департаменты директоры. Т. җитәкчелек иткән вакытта «Байкал» хуҗалыгында 50 тракторга исәпләнгән ремонт остаханәсе, урта мәктәп, 2 балалар бакчасы, 2 кибет һәм башка җитештерү объектлары, социаль-мәдәни һәм көнкүреш биналары төзелә. 1984–94 тә бөртекле ашлык җитештерү 42,3% ка, сөт — 14,4% ка, бөртеклеләрнең уңышы — 1 *га* дан 11,3 *ц* га, һәр сыердан еллык савым уртача 344 *кг* га арта. Хуҗалыкның табышлылык дәрәҗәсе 1% тан 52% ка кадәр күтәрелә. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ТАЛИ́ПОВ** Сәлим Билал улы (апр., 1906, Уфа губ., Златоуст өязе Лаклы а. — ?), агроном икътисадчы, хакимият-хуҗалык хезмәткәре. К.А.Тимирязев исем. Мәскәү а.х. академиясен тәмамлый (1931). 1920–22 елларда ВЛКСМның Лаклы р-н ком-ты секретаре, Лаклы авыл советы секретаре, рәисе (1923 елдан). 1931–33 тә СССР Игенчелек Халык комис-тында агроном-икътисадчы, 1936–40 та план бүлеге секторы башлыгы. 1934–35 тә Кырым АССРның Джанкой р-ны «Бейсу-Ковче» с-зында агроном. 1935–36 да Калинин өлкәсе Игенчелек Халык комис-тының планлаштыру бүлегендә өлкән агроном. 1940–43 тә Чиләбе өлкәсендә партия эшендә. 1943–46 да ТАССР игенчелек халык комиссары, 1946–48 дә ТАССР а.х. министры. 1948 дән СССР А.х. министрлыгында һәм СССР Мамык җитештерү министрлыгында. 1947–48 дә ТАССР ЮС, 1947–51 дә РСФСР ЮС депутаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* А й м е т д и н о в А.М. Первые наркомы на селе // Татарстан. 2008. № 1/2.

*И.Н.Афанасьев.*

**ТАЛКЫ́Ш** елгасы, Көнбатыш Кама арьягында, Чишмә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 49 *км*. Бассейнының мәйданы 527,8 $км^2$. Елга башы Чистай р-ны Яңа Урал авылыннан төньяктарак, тамагы Түбән Кама р-ны Свердловец посёлогы янында. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Т.ның 2 дән 24,7 *км* га кадәр озынлыктагы 11 кушылдыгы бар, иң зуры — Каргалы елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,23 $км/км^2$. Т.ның су җыелу мәйданы аз гына калкулыклы төньяк-көнчыгышка авыш тигезлектән гыйбарәт: субүләрләрнең абс. биеклеге 100–150 *м*. Елга үзәненең сөзәклекләре бертөсле текәлектә, сыза һәм ерымнардан тора. Т. бассейнының шактый өлеше сукаланган. Үсемлекләр дөньясы катнаш урманнардан тора. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Елга юлы бормалы, тармакланмаган. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 3 $л/с \cdot км^2$. Гидрологик режимы ташу



Талкыш елгасы түбән агымында.

вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 115 *мм*, ташу агымы катламы 109 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана һәм уртача 24 көн дәвам итә. Су биеклегенең уртача еллык тирбәнешләре 2,7 *м* (макс. 3 *м*). Җәйге челләдә су биеклеге тотрыклы, яңгыр ташкыннары сирәк һәм сизелерлек үзгәреш ясамый, алар уртача 1–2 көн дәвам итә. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,11 $м^3$/с. Кышкы челлә ноябрь башында башлана. Боз капламы тоташ, кыш ахырына уртача калынлыгы 86 *см* га (макс. 158 *см*) җитә. Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Т. бассейнында суының гомуми күләме 4,7 млн. $м^3$ тәшкил иткән 4 буа бар. Су ресурслары сугару һәм а.х. пр-тиеләрен су б-н тәэмин итү өчен файдаланыла. Т.ның су җыелу мәйданы көчле антропоген йогынтыга дучар. Урманнарны кисү һәм җирләрне сукалау ерымнар эрозиясе тудыра. Т. — ТРның табигать истәлеге (1978).

*О.Н.Урбанова.*

**ТАЛКЫ́Ш** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 34 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 68 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 нән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Толкиш, Толкишка исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Изге Гурий бoрадәрлеге мәктәбе (1872 дә ачыла), вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 307,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Ключище волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Питрәч, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 36 ир-ат; 1859 да — 166, 1897 дә — 245, 1908 дә — 326, 1920 һәм 1926 да — 355, 1938 дә — 285, 1949 да — 395, 1958 дә — 257, 1970 тә — 273, 1979 да — 209, 1989 да — 123, 2002 дә — 73 кеше.

**ТАЛЛЫБУЛӘ́К** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 18 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Сарсаз елгасыннан 4 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 176 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 1920 еллар башында нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Бәйрәкә волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 10 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1922 дә — 202, 1926 да — 231, 1938 дә — 325, 1949 да — 236, 1958 дә — 189, 1970 тә — 270, 1979 да — 149, 1989 да — 126, 2002 дә — 162 кеше.


**ТАЛЛЫБУЛӘ́К** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 6 *км* төньяк-көнбатыштарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 246 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, ат асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. Мәчет. 1930 елларда нигез салына. Беренче исеме — Грязнушка, 1940 еллардан хәзерге исемен йөртә. Халык саны: 1958 дә — 139, 1970 тә — 230, 1979 да — 196, 1989 да — 157, 2002 дә — 214 кеше.

**ТАЛЛЫКҮ́Л** посёлогы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 38 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 229 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1931 дә нигез салына, 1993 кә кадәр — «Баулы» совхозының 1 нче бүлекчәсе. Оешкан көненнән Баулы р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1989 да — 265, 2002 дә — 242 кеше.

**ТАЛПАННА́Р** (Acarina), үрмәкүчсыманнар классыннан буынтыгаяклылар төркеме. Җир өстендә яшәүче умырткасызларның иң борынгы төркемнәреннән берсе. 3 отрядны берләштерә: акариформалы Т. (Acariformes), паразит Т. (Parasitiformes) һәм печәнче Т. (Opiliocarina). Дөнья фаунасында 20 меңнән артык төр исәпләнә. Озынлыклары 0,05–1,5 *мм*, кан б-н туенучыларныкы — 15 тән 22 *мм* га кадәр. Үсеш циклы үз эченә күкәй, алты аяклы личинка, аның артыннан сигез аяклы нимфаль (1–3) һәм олы формаларны ала. Печәнче Т. аеруча гади булып исәпләнә, аларда гәүдәнең сегментлашуы саклана. Бу отряд вәкилләре — зурлыклары буенча вак ерткычлар, җылы климатлы континент урманнарында таралганнар, аз өйрәнелгәннәр. Акариформалы һәм паразит Т.ның гәүдә сегментлашуы сакланмаган; алгы өлеше — 4 пар аяк һәм төрлечә туенуга (фито-, сапро- һәм гематофаглар, ерткычлар) җайлашкан авыз органнары б-н баш-күкрәктән, арты баш-күкрәк б-н кушылган корсактан тора.

Акариформалы Т. отрядында 15 меңнән артык төр исәпләнә һәм 2 семьялык төркемен үз эченә ала: *су талпаннары* (Hydracarina), *каты кабыклы талпаннар* (Oribatei); 4 өссемьялык: *оры талпаннары* (Tetrapodili), *пәрәвезле талпаннар* (Tetranychoidea), *каурый талпаннары* (Analgesodiea), *кычыттыргыч талпаннар* (Sarcoptoidea); семьялыклар: *амбар талпаннары* (Acaridae, Tyroglyphoidae), *төкле талпаннар* (Miobiidae, Listrophoroidae), *кызыл тәнле талпаннар* (Trombiculidae), биз Т.ы (Demodecidae), каләмлек Т. (Syringophilidae) h.б.

Паразит Т. отряды 2 өссемьялыкны берләштерә: иксод (Ixodoidea) һәм гамаз (Gamasoidea) Т. Беренче өссемьялык аргас һәм иксод Т.ның 800 дән артык төрен үз эченә ала. Болар кан суыручылар, барлык континентларда да киң таралганнар, умырткалы хайваннарда паразитлык итәләр. Иксод Т. кеше һәм хайваннарда вируслы, бактериаль, протозойлы табигый тупланыш авыруларын иң көчле таратучы һәм резервуар исәбенә керә.




Талпаннарның төп төркемнәре вәкилләре.
Акариформалы талпаннар:
1 — каты кабыклы (Eremobella sp.); 2 — су (Copydognathus fabricii); 3 — пәрәвез (Tetra nychus urticae); 4 — орылар (Eriophyes vitis); 5 — кызыл тәнле (Trombicula autumnalis), 5 а — аның личинкасы; 6 — каурыйлы (Zachvatkinia sternae); 7 — төкле (Listrophorus gibbus); 8 — кычыттыргыч (Psoroptes sp.).
Паразит талпаннар:
9 — иксод (Ixodes persulcatus), 9 а — аның личинкасы; 10 — гамаз (Hirstionyssus sp.).

Гамаз Т. 20 семьялыкка караган 5 меңнән артык төрне үз эченә ала. Аларның яшәү рәвеше төрле: иректә яшәүче ерткычлар һәм сапрофаглардан алып рептилия, кошларда, имезүчеләрдә вакытлыча экто- яки даими эчке (тән куышлыгында яшәүче) паразитларга кадәр. Кайбер кан суыручы төрләр трансмиссив табигый тупланыштагы инфекция йоктыручыларны тараталар. Т. — космополитлар: туфракта, суда, үсемлекләрдә, хайван оялары һәм өннәрендә очрыйлар; күп кенә төрләре — паразитлар. Хайван тәнендә урнашу урынына карап тире өстендә, тиредә, тире астында, каурый һәм тән куышлыгында яшәүчеләргә, ә хуҗасы б-н бәйләнеш дәрәҗәсе буенча вакытлыча һәм даимигә бүленәләр. Т.ның күп кенә төрләре азык-төлекне зарарлый.

Татарстан терр-ясендә акариформалы һәм паразит Т.ның күп кенә таксономик төркемнәре бар. Аеруча иксод, кызыл тәнле, каурый, *гамаз талпаннар* — кошлар һәм имезүчеләрнең эктопаразитлары, ш.у. каты кабыклы һәм гамаз Т.ның җирдә яшәүче ерткыч һәм сапрофит формалары өйрәнелгән. Республика терр-ясендә нутталиоз, пироплазмоз, туләрәмә, талпан боррелиозы, талпан энцефалитының табигый тупланышларында иксод һәм гамаз Т.ның кайбер төрләренең эпизоотик һәм эпидемиологик әһәмияте исбатланган.

*Әд.:* Б о й к о В.А. Природные очаги клещевого энцефалита в лесостепной зоне Среднего Поволжья: Автореф. дис. ... М., 1975; Б о й к о В.А., И в л и е в В.Г., А ю п о в А.С. Иксодовые клещи в лесах Среднего Поволжья. К., 1982; Эктопаразиты птиц в Среднем Поволжье. Ч. 1. Клещи. К., 1991; Паразитология и инвазионные болезни животных. М., 2000; Природные очаги зооантропонозов трансформированных ландшафтов Республики Татарстан во второй половине XX века. К., 2001.

*В.А.Бойко.*

**ТАЛЧАЛА́Р** (Salicaceae), ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. Агачлар яки куаклар, кайвакыт куакчыклар. 3 ыругны һәм якынча 400 төрне үз эченә ала. Башлыча Төньяк ярымшарның уртача һәм салкын поясларында таралганнар. ТР терр-ясендә 2 ыруттан (*тал* һәм *тополь*) 22 төре бар. Яфраклары бөтен, чиратлашып урнашкан. Чәчәкләре вак, чәчәк тирәлеге юк, башка алкаларга җыйналган, ата затларда ул алкалар чәчәк атканнан, аналарда орлыклары өлгергәннән һәм сибелгәннән соң коелалар. Тал чәчәкләре утырма, топольләрдә — чәчәк сапларында. Тал чәчәкләренең чәчәк тирәлеге юк (аның урынына 1–3 баллы вак бизчек); топольләрдә нектарлыклар юк (касәсыман чәчәк тирәлеге бар). Җимеше — бик күп вак орлыклы бер оялы тартмачык. Орлыклары бүрекчәле һәм юка төкчәле, җил б-н шактый ерак араларга җиңел күчә. Яктылык һәм дым яратучы үсемлек. Саклагыч утыртылмаларда үстерелә. Парк һәм сулык ярлары буенда декоратив таллар (аеруча еламсар формалары киң таралган) утырталар. Үзагачын — төзелеш материалы буларак йорт җиһазлары, фанера җитештерүдә, кабыгын тире иләүдә кулланалар. Баллы үсемлекләр. 3 төре (лапландия талы, кара җиләксыман тал, розмарин яфраклы тал) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ТАЛЬГРЕ́Н** (Tallgren) Арне Михаэль (8.2.1885, Руовеси, Бөек Финляндия кенәзлеге — 13.4.1945, Хельсинки, Финляндия), фин археологы, философия д-ры (1911), публицист, җәмәгать эшлеклесе. Турку шәһәре лицеенда, Александр (хәзер Хельсинки) ун-тында укый (1903–07). Фин-угор археологиясенә нигез салган Й.Р.Аспелин шәкерте. 1906 елдан Дәүләт (1918 дән Милли) тарих музее (Гельсингфорс ш.) ассистенты; 1913 тән секретаре. 1919–20 дә Хельсинки ун-тының Урал-Алтай археологиясе доценты, 1923–45 тә фин һәм Скандинавия археологиясе профессоры. 1920–23 тә Тарту ун-тында (Эстония) археол. профессоры. Бер үк вакытта Фин археол. җәмгыяте секретаре (1918–30), рәисе (1930–36, 1939–42) һәм аның «Eurasia Septentrionalis Antiqua» басма органы мөхәррире (1926–38). Казан ун-ты каршындагы Археол., тарих һәм этнография җәмгыятенең мөхбир әгъзасы (1915). Т. күп мәртәбәләр Россиядә һәм СССРда (1908, 1909, 1915, 1917, 1924, 1925, 1928 һәм 1935), ш.и. Казанда (1908) була; Казан галимнәре һәм музей эшлеклеләре Н.Ф.Катанов, В.Ф.Смолин, М.Г.Худяков, Н.Ф.Калинин, Б.Ф.Адлер һ.б. б-н хатлар аша аралашып тора; Казан губернасы терр-ясендә археол. казу эшләре алып бара («Саескан Тавы» шәһәрлеге, Маклашеевка курганнары һ.б.). Хезмәтләре Көнчыгыш Европаның (ш.и. Урта Идел буеның) бронза һәм тимер гасырлар археологиясенә, Финляндиядә археол. фәне тарихы һәм библиографиясе, төбәкне өйрәнү хәрәкәте мәсьәләләренә карый. В.И.Заусайловның борынгы һәм урта гасырлар табылдыкларыннан торган археол. тупланмасын бастырып чыгара (к. *Заусайлов коллекциясе*). Археол. өлкәсендәге казанышлары өчен 1940 та Лондон борынгылыкны сөючеләр җәмгыяте тарафыннан «Археология өлкәсендә аеруча хезмәт күрсәткәне өчен» алтын медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Die Kupierund Bronzezeit in Nord- und Ostrussland. I. Die Kupferund Bronzezeit in Nordwestrussland. Die altere Metallzeit in Ostrussland // Suomen Muinaismuistoyhdistyksen aikakauskirja. 1911. T. 25; Collection Zaouissailov au Musee histirique de Finlande a Helsingfors. I. Catalogue raisonne de la collection de I'age du bronze. Hels., 1916; Collection Zaouissailov au Musee National de Finlande a Helsingfors. II. Monographie de la section de I'age du fer et L'epoque dite de Bolgary. Hels., 1918; L'epoque dite d'Ananino dans la Russie orientale // Suomen Muinaismuistoyhdistyksen aikakauskirja. 1919. T. 31.

*Әд.:* K i v i k o s k i Ella. The Bibliography of A.M.Tallgren // Eurasia Septentrionalis Antiqua, Supplementary Volume. Hels., 1954; S a l m i n e n Timo. Suomen tieteelliset voittomaat. Venaja ja Siperia suomalaisessa arkeologiassa 1870–1935 // Suomen Muinaismuistoyhdistyksen aikakauskirja. 2003. T. 110.

**ТАЛЬКО́ВСКИЙ** Искәндәр Искәндәр улы (Александр Александрович) (18.9.1894, Кельце губ., Мехов өязе Новобржеск пос. — 23.2.1942), генерал-майор (1931). Польша-Литва татарларыннан. Павел хәрби уч-щесен (С.-Петербург, 1914), Эшче-Крәстиян Кызыл Армиясе Хәрби академиясе каршындагы Югары командирлар составы югары курсларын (Мәскәү, 1923), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академиясе каршындагы югары командирлар составының белемен күтәрү курсларын (Мәскәү, 1929) тәмамлый. Беренче бөтендөнья сугышы фронтларында 1915 нең гыйнварыннан, запастагы батальонның ярымротасы командиры, атлы разведчиклар командасы башлыгы, 2 нче гв. пехота дивизиясенең Павловск лейб-гвардия полкында батальон командиры. Төньяк-Көнбатыш, Көнбатыш һәм Көньяк-Көнбатыш фронтлары гаскәрләре составында Ломяра, Брест-Литовск, Вильно, Луцк, Тарнополь (хәзер Тернополь) торак пунктлары тирәсендәге сугышларда катнаша. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң 2 нче гв. пехота дивизиясенең полк солдатлар ком-ты рәисе урынбасары. 1917 дән Кызыл Армиядә. 1917–18 дә — Петроград мөселман солдатлар полкы командиры. 1918 нең июль–декабрендә 1 нче Петроград эшче укчылар дивизиясенең 2 нче укчылар полкы командиры. 1919 ның гыйнвар–апрелендә Кызыл Армия командирлар составының ике Казан мөселман пехота курсларында строй бүлеге башлыгы. 1919–20 дә штаб башлыгы, 1 нче Аерым Идел буе татар укчылар бригадасы командиры, Көнчыгыш фронт гаскәрләре составында Урал һәм Оренбург ак казакларын, адмирал А.В.Колчакның Көньяк армиясен, Төркестанда басмачыларны тар-мар итүдә катнаша. 1921–22 дә кызыл командирларның 4 нче һәм 6 нчы Төркестан аерым укчылар бригадасы командующие. Фирганәдәге милләтче гаскәри частьны юк итү операциясен җитәкли, Семиречьедагы Нарым кузгалышларын бастыруда катнаша (1921). 1923–31 дә ТАССР ҮБК исем. Берләшкән татар-башкорт хәрби мәктәбе башлыгы, хәрби комиссары. 1931–37 дә Кырым АССР ҮБК исем. 3 нче Кырым укчылар дивизиясе командиры. 1940–41 дә М.В.Фрунзе исем. Хәрби академия укытучысы, курс башлыгы. 1938 һәм 1941 дә нахакка репрессияләнә; атып үтерелә. 1956 да аклана. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г р и ш и н Я., Ш а р а ф у т д и н о в Д. На службе Родине. К., 2005.

*Д.Р.Шәрәфетдинов.*

**ТАЛЬКО́ВСКИЙ** Искәндәр (Александр) Осман улы (14.5.1858, Вильно губ., Вымянск өязе Кырык Татар а. — 1922, Баку), генерал-майор (1910). Польша-Литва татарларыннан. Вильно юнкерлар пехота уч-щесен тәмамлый (1875). 1873–76, 1878–85 елларда унтер-офицер, 107 нче Троицк пехота полкының рота командиры. 1877–78 дә прапорщик, 9 нчы Себер гренадёрлар полкы подпоручигы; полк составында 1877–78 дәге рус-төрек сугышында катнаша. 1885–88 дә Завихот чик сакчылары бригадасы офицеры, Опатовец отряды командиры. 1889–96 да бригада мәхкәмәсе әгъзасы, офицерларның заём капиталы кассиры, Новобржеск чик сакчылары бригадасы ротмистры. 1898–1902 дә Чик сакчылары корпусы штабында өлкән адъютант ярдәмчесе. 1902–05 тә Аерым Керчь бүлеге командиры. 1906–12 дә Кара диңгез бригадасы командиры. 1912–14 тә 4 нче Рига чик сакчылары бригадасы командиры. 1915 тән Беренче бөтендөнья сугышы фронтларында: Виндава шәһәре һәм Виндава отряды гарнизоны башлыгы, соңрак Балтыйк яр буе сакчылар отрядының Виндава р-ны башлыгы. 1916–18 дә Петроград һәм Двина хәрби округлары штабы каршындагы хезмәткәрләр әзерләүче запас гаскәрдә. Кызыл Армиядә 1918 дән, 1 нче укчылар дивизиясенең (Петроград) 1 нче бригадасы командиры, Петроград хәрби округының Мөселман хәрби советы башкарма ком-ты әгъзасы. 1919–20 дә Кызыл Армиядә командирлар составының 2 нче Казан мөселман пехотачылар курслары мөдире. 1920 нең августыннан Бакудагы 11 нче армия штабы архивы башлыгы. 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә Изге Анна ордены, 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 1 нче, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г р и ш и н Я., Ш а р а ф у т д и н о в Д. На службе Родине. К., 2005.

*Д.Р.Шәрәфетдинов.*

**ТАМАКСА́**, татар хатын-кызларының бизәнү әйбере, баш-башлары түгәрәкләнеп килгән ярымай рәвешендәге муен асмасы, күкрәк өстенә төшереп киелә. Тупас киндердән каты аслыкка утыртыла, өсте караңгы төстәге тукыма б-н тышлана. Ярымайның эчке кырые буйлап якты төсләрдәге (куе алсу, кызыл, кишер сары) кант уздырыла. Т.га 2–3 рәт итеп тәңкәләр (аскы рәткә, гадәттә, көмеш тәңкәләр), мәрҗәннәр тагыла, өске өлеше бака кабырчыклары б-н бизәлә. Элмәк-ыргак

яки төймә ярдәмендә беркетелә. Бу төр муенса-түшлек яшүсмер кызларга атап эшләнгән, кияүгә чыкканчы даими киелгән. 19 йөз урталарында Казан татарлары, аеруча керәшен татарлар арасында таралыш алган. Уфа губернасының Бәләбәй һәм Минзәлә өязләрендә, Оренбург губернасының



Керәшен татарлар тамаксасы.

Богырыслан өязендә «муенса» дип йөртелгән. 19 йөз ахыры — 20 йөз башларында Т.ның кулланылыш даирәсе тарая, керәшен татарлар яши торган терр-яләр б-н чикләнә.

*Әд.*: Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Суслова С.В., Мухамедова Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала. К., 2000.

**«ТАМАШАЧЫ́»**, айлык рәсемле журнал. Татар акад. театры органы. 1927–30 елларда Казанда татар телендә нәшер ителә, якынча 30 саны чыга. 1927–28 дә «Татар дәүләт академия театры мәҗмуга-программасы» исеме б-н дөнья күрә. 1930 да латин графикасында басыла. Составында М.Зәитов, Г.Гали, Ш.Госманов, Г.Кутуй, Х.Кәримов булган мөхәрририят тарафыннан әзерләнә. Актив авторлары арасында — С.Атнагулов, С.Габәши, Г.Минский, З.Солтанов, Ш.Шамильский һ.б. Журнал реалистик сәнгать позициясендә тора, сәхнәдәге декадентлык һәм модернизмга каршы көрәшә, татар милли театрының үсеш перспективалары турында фикер алышулар оештыра. Татар акад. театры, Россиянең Мәскәү, Әстерхан, Оренбург, Стәрлетамак, Уфа һ.б. шәһәрләре татар театрлары эшчәнлеген яктырта. Спектакльләргә («Зәңгәр шәл», «Сүнгән йолдызлар», «Галиябану» һ.б.) рецензияләр, театр сценографиясе, драматургиясе, икътисады һәм социологиясенә багышланган мәкаләләр бастыра. 1928 дә журнал битләрендә Б.А.Лавренёвның З.Солтанов тәрҗемәсендәге «Разлом» пьесасы буенча куелган спектакль турында фикер алышу уза. 1929 да милли театрда форма проблемалары турында фикер алышына. Татар актёрлары, режиссёрлары, драматурглары, рәссамнары, композиторлары турында истәлекләр һәм очерклар басыла.




«Тамашачы» журналы.

*З.З.Гыйләҗев.*

**ТАМГА́**, 1) үзенчәлекле билге, тамга, яндырып салынган тамга; мөһер яки аның эзе. «Т.» термины 7–11 йөзләрдә төрки һәм уйгыр язма истәлекләрендә теркәлгән. Иң беренче ул аерым шәхеснең, ыруг яки кабиләнең милеккә хуҗа булуын белдерү өчен кулланыла («яндырып салынган тамга»ның мәгънәсе шуннан), терлеккә тамга салу өчен файдаланыла. Борынгы төрки җәмгыятьтә язу барлыкка килү һәм эш башкару үсеше алга китү б-н, термин яңа мәгънә ала — «мөһер» (яки «мөһер эзе»), ул идарәченең шәхесен һәм рәсми дәрәҗәсен раслый. Парлы «Т.-нишан» термины кулланылу очраклары да билгеле. Башка төркиләрдә «Т.» терминының ясалма формасы — тамгачы (мөһерне саклаучы) сүзе дә кулланылган. «Т.» сүзе ш.у. төргәккә төрелгән хатларны һәм савытны мөһерләп кую чарасы мәгънәсендә дә кулланыла. Милек билгесе һәм имза алмаштыргыч буларак «Т.» татарлар, башкортлар, казакълар һ.б. төрки халыклар тарафыннан яңа дәвергә кадәр файдаланыла. 13 йөздән башлап «Т.» (мөһер) барлык Чыңгызыйлар дәүләтләрендә киң тарала. Хан Т.сы квадрат формасында (5,5×5,5 *см* яки 15×15 *см* зурлыгында) һәм төсләре б-н төрле (сары (алтын), ал һәм зәңгәр) була. Чыңгызыйларның элгәреге кв. Т.ларының текстлары күбесенчә төрки телдә уйгыр язуы б-н, Урта Азия һәм Иранда ш.у. гарәп язуы (сөлес) б-н язылган. Алтын Урдада һәм ул таркалганнан соң барлыкка килгән татар ханлыкларында Т. текстлары фәкать Алтын Урда төрендәге куфи почеркы б-н языла. Квадрат Т. тексты берничә компоненттан — дини тәгълиматтан, девиз, хан исеме эпитетыннан, мөһер хуҗасы исеменнән, теләк-фатихадан, патшалык итүче йорт гербыннан тора. Җүчиләрнең соңгы чор актларында «Т.», «*нишан*» һәм «*мөһер*» терминнары синонимнар буларак кулланылалар. 16 йөз ахырыннан кв. Т. гамәлдән чыга.

2) Монголлар тарафыннан кертелгән акча салымы, акчалата җыем. «Т.» терминының эчтәлеге бу очракта Чыңгызыйлар дәүләте составына кергән илләргә хас. «Т.» терминының «мөһер»дән «салым»га үзгәрүе «мөһер өчен түләү» төшенчәсе аша уза. Терминның мәгънәсе төрле төбәкләрдә төрлечә була: берәүләрендә ул — сәүдәгәрләрдән, һөнәрчеләрдән, төрле кәсепчеләрдән җыелган төп салым, икенчеләрендә — чик буе пунктларында товарлардан акчалата җыем, өченчеләрендә а.х. продуктларыннан салым хисаплана. Терминның яңа эчтәлегенә туры китереп, «сәүдә итүчеләрдән салым һәм пошлина җыю эшләрен башкаручы түрә» мәгънәсендә яңа исем (титул) — «тамгачы» барлыкка килә.



Җүчиләр йорты тамгасы сугылган тәңкәләр. 13–14 йөзләр.

Россиядә «Т.» атамасы 13–15 йөзләрдә сәүдә килешүләренә карата кулланыла.

*Әд.:* Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. К., 1979.

*М.Г.Госманов.*

**ТАМГАЧЫ́** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 44 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычыннан 1,5 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 203 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Клуб. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Томгачи, Перепутье, Ятманы, Ятманка исемнәре б-н дә билгеле. Халкы башта татар морзалары Яушевлар карамагында була, 18 йөздә бер өлеше Уфа губернасына, икенче өлеше күрше Сиңгел авылына күченә. Рус крәстияннәрен (Пенза губ-насыннан күченүчеләр) монда 18 йөз ахырында алпавыт Молоствов урнаштыра. 1799 да авыл — алпавыт А.Н.*Родионова*, 1820 елларда полковник Мергасов милкенә күчә. Халкы игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, түбә ябу, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да земство мәктәбе (1883 тә ачыла), җил тегермәне, ярма яргыч, 2 тимерче алачыгы, 2 вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 616 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Әстерхан волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 123, 1859 да — 176 ир-ат; 1897 дә — 622, 1908 дә — 660, 1920 дә — 675, 1926 да — 779, 1938 дә — 634, 1949 да — 419, 1958 дә — 343, 1970 тә — 256, 1979 да — 172, 1989 да — 109, 2002 дә — 210 кеше.

**ТАМО́ЖНЯ**, барлык төр транспорт чаралары б-н чит илгә товар чыгару, чит илдән товар кертү һәм транзит турындагы законның үтәлешен тәэмин итүче һәм шул операцияләргә бәйле рәвештә пошлина һәм салым алучы дәүләт учреждениесе. Т.ның төп функциясе — транзит йөкләрнең документларына тәңгәллеген, контрабанда товарлары булмавын ачыклау, таможня пошлиналары салу. Татарстанда Т. эшенең тамырлары Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чорларына барып тоташа. Казан Көнбатыш һәм Көньяк-көнчыгыш илләре сәүдәсендә арадашчы була, һәм биредә таможня сәясәте чаралары киң файдаланыла. М.Г.Худяков раславынча, «Сәхибгәрәй ярлыгы»нда «тамгачы»лар — застава һәм таможняларда пошлина җыючы чиновниклар искә алына.

16 йөз ахырыннан, Казан ханлыгын Рус дәүләтенә кушканнан соң, Казан яңадан Көнчыгыш б-н Көнбатыш илләре сәүдәсендә арадашчы була, Т. эше үсүен дәвам итә. 17 йөз ахырында — 18 йөз башында Казанда таможня бинасы Гостиный двор б-н янәшә (Кремльнең Спас манарасы каршында) була. Салым язулары Т.ның керем кенәгәләрендә теркәлә, җыелган салым җирле ихтыяҗларга тотыла. Авыр җыем-салымнар җирле сәүдә үсешен тоткарлаганлыктан, 18 йөз уртасында император Елизавета Петровна Фәрманы б-н Россия терр-ясендәге эчке Т.лар бетерелә. 1986 елда, Казан аэропортына халыкара статус бирелгәч һәм Казан таможнясы булдырылгач, Татарстанда Т. эше яңара. 1989 да тышкы сәүдәгә дәүләт монополиясе бетерелгәч, Т. яңа үсеш ала. 1993 тә Казан Т.сы җирлегендә — Татарстан Т. идарәсе, 2001 дә 6 Т. посты: «Казан» аэропорты, Әлмәт, Алабуга, Казан, Чаллы, Түбән Кама постлары составында Татарстан Т.сы оеша. Татарстан Т.сы — Идел буе төбәгенең иң эре Федераль Т. хезмәте бүлекчәләреннән берсе.

Т.ның төп бурычы — тикшерүче, контроль ясаучы гына булудан югары сыйфатлы хезмәт күрсәтүче (сервис-контроль) ролenә күчү. «Бер тәрәзә» режимында эшләү схемасы дәүләт чигендәге пунктларда Т. контроленең технологиясен үзгәртүне күздә тота. Йөк ташучы тиешле контроль органнарын эзләүдән азат ителә, һәртөрле контрольләр узуга китәсе вакытны янга калдыра. Үткәрү пунктында транспорт чарасы 1 сәгатьтән дә артык тоткарланмаска тиеш була. Тышкы сәүдә әйләнешен тизләтү өчен электрон декларация, алдан хәбәр итү, электрон имзалар системасын файдалану һ.б. заманча мәгълүмат технологияләрен куллану практикасы киңәя. 2015 тә тышкы сәүдә операцияләренең күләме 6,5 млрд. АКШ долларыннан артыграк тәшкил итә; федераль бюджетка 22 млрд. сумнан артыграк акча күчерелә.

**ТАМЧЫ́ ГӨЛ** (Fuchsia), кырлыганчалар семьялыгыннан үсемлекләр ыругы. 100 гә якын төре, 2 меңнән артык кушылгак сорты билгеле. Чыгышы — Үзәк һәм Көньяк Америка, Яңа Зеландия. Яфраклары каршыдаш яки әвернә торышлы, сирәк кенә чиратлашкан. Чәчәкләре иенке, кыңгырау формасында, озын чәчәк сапларында, берле яки чук чәчәк төркемендә, аскы җимшәнле. Формасы, зурлыгы, катмарлык дәрәҗәсе, касә һәм таҗының төсе буенча аерылалар. Җимеше — җиләк. ТРда кайбер кушылгак сортларын үрчетәләр: кушылгак Т.г. (F. hybrita), Техас Т.г.е (F. texas), Талия Т.г.е (F. Thalia) һ.б. Ботактан үрчи. Язын, озынлыгының өчтән бер өлешен калдырып, ботакларын кисәләр. Үсемлеккә форма бирү өчен, даими кискәләп тору мөһим. Ел саен күчереп утырталар. Үсемлек яктылык ярата, әмма туры кояш нурлары һәм югары темп-ра аңа начар тәэсир итә. Чәчәк аткан килеш озак утыралар. Чәчәк ату чорында күчереп йөртү киңәш ителми: чәчәкләрен һәм чәчәк бөреләрен коярга мөмкин. Яфракларын коя, язын яңалары чыга.

**ТАМЫ́Р ҮРЧЕНЛЕ́ ЧҮП ҮЛӘННӘ́Р**, күпьеллык үләнчел үсемлекләр. Вегетатив-тамыр үсентеләр ярдәмендә үрчиләр. Авыр бетерелә торган чүп үләннәр төркеме. Туфракка тирән китә торган (6–7 *м*) көчле тамыр системасы һәм яхшы үскән ян тамырлары б-н аерылып тора. Соңгылары 3 яруста урнаша: беренчесе — 14–16 *см* тирәнлектә, икенчесе — 50–60 *см*, өченчесе — 80–100 *см*. Төп тамырда, шулай ук ян тамырларында бөреләр урнашкан (1 *м² га* 500 данәдән 1500 гә кадәр), алардан яхшы шартларда яңа үсемлекләр үсә. Механик зарарлану бөреләрнең бердәм үсеп китүенә китерә. Җәй дәвамында вегетациянең 4 чоры була: 1) кыштан соң яшь үрентеләр барлыкка килү, 2) горизонталь тамырлар һәм тамыр үрченнәре барлыкка килү, 3) туклыклы матдәләрнең тамырларда тупланувы, 4) тыныч халәттә булу. Т.ү.ч.ү.дән ТР терр-ясендә кыр билчәне яисә сары билчән, эт әчәгесе, эт какысы, кыргый салат, шуышма ачыкый киң таралган.

**ТАМЫРЧАЛЫ́ ЧҮП ҮЛӘННӘ́Р**, күпьеллык үләнчел үсемлекләр, вегетатив юл б-н, тамырчалар ярдәмендә үрчиләр. Тамырчалары аерым әгъзалардан тора һәм яралгы яфраклар барлыкка килә, аларны ян бөреләр каплый (1 *м² га* 20–25 мең данә). Тамырчаларында туклыклы матдәләр туплана, алар яңа үсемлекләр барлыкка килү өчен кирәк. Тамырчаларның тирәнгә китүе 10–12 *см* тәшкил итә. Тамырчаларын механик зарарлаганда бөреләре табигый шартлардагыга караганда 3–4 тапкыр күбрәк үсә. Т.ч.ү.гә шуышма *сарут*, кыр наратбашы, сабаклы тарлау һ.б. керә. ТРда шуышма сарут һәм кыр наратбашы киң таралган, алар барлык культура чәчүлекләрен чүплиләр.

**ТАНА́Й** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында. Озынлыгы 31,2 *км*. Бассейнының мәйданы 175,5 *км²*. Алабуга р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Олы Качык авылыннан 9 *км* төньяк-көнбатыштарак, Танай авылыннан 1 *км* көньяк-көнбатыштарак Криуша Кама ермагына коя. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Т.ның 0,9 дан 5,8 *км* га кадәр озынлыктагы 14 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,39 *км/км²*. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 122 *мм*, ташу агымы катламы 110 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,075 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Т. бассейнында суының гомуми күләме 2,8 млн. *м³* булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ТАНА́Й** посёлогы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 29 *км* көнбатыштарак, Нөгеш елгасы буенда. Даими яшәүчеләр юк. 20 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Аккирәй ширкәте посёлогы буларак телгә алына. 1910 да авыл җәмгатенең имана җире 300 дис. тәшкил итә. Оешкан көненнән Самара губернасының Бөгелмә өязе Әлки волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1910 да — 160, 1920 дә — 166, 1926 да — 199, 1938 дә — 232, 1949 да — 152, 1958 дә — 109, 1970 тә — 49, 1979 да — 14, 1989 да — 9, 2002 дә — 3 кеше (татарлар).

**ТАНА́Й** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 10 *км* көнбатыштарак, Танай елгасы буенда. 2010 елда 1659 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү. 1646 дан Тана авылы буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Архангельский исеме б-н дә билгеле. Халкы башта таш (Шайтан) каланың Троица ирләр монастырена карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышында* Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында Михаил-Архангел чиркәве (1806–33 тә төзелә; архит-ра истәлеге), 2 сыйныфлы чиркәү-приход мәктәбе (бина 1890 еллар башында сәүдәгәр Ф.П.Гирбасов иганәсенә салына) эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 7932 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Лекарево волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга р-нында. Халык саны: 1905 тә — 3356, 1920 дә — 3109, 1926 да — 3143, 1938 дә — 2504, 1949 да — 1844, 1958 дә — 1582, 1970 тә — 1676, 1979 да — 1261, 1989 да — 1279, 2002 дә — 1497 кеше.

**ТАНА́Й** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 14 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Үләмә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 5 кеше (руслар) яши. 1646–52 дә Пустошь Тонаикова исеме б-н мәгълүм. Авыл башта — татар морзалары Ишеевлар, соңрак рус хуҗалары карамагында була. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1896 да ачыла), 2 җил тегермәне, 2 тимерче алачыгы, 3 вак-тәяклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 872,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Никифоровка волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 265 ир-ат; 1859 да — 649, 1897 дә — 816, 1908 дә — 975, 1920 дә — 788, 1926 да — 830, 1938 дә — 597, 1949 да — 408, 1958 дә — 207, 1970 тә — 107, 1979 да — 62, 1989 да — 21, 2002 дә — 7 кеше.

**ТАНА́Й КОМ-ЧУЕРТА́Ш ЧЫГАНАГЫ́** (Танай 1-П), Алабуга шәһәреннән 4–5 *км* түбәндәрәк, Кама елгасы тугаенда; ТРдагы иң зур чыганакларның берсе (запасы 60 млн. $м^3$ дан артык). 1961 елда табыла, соңыннан чималның запасларын ачыклау буенча берничә тапкыр өстәмә эшләр үткәрелә. Казан һәм Чаллы елга портлары тарафыннан 1970 елларга кадәр эшкәртелә. Чимал респ-кадагы һәм күрше төбәкләрдәге төзелешләргә җибәрелә. Хәзер үзәк өлеше вакыт-вакыт Чаллы һәм Алабуга шәһәр оешмалары тарафыннан үзләштерелә. Өске капламының калынлыгы 0,4–10 *м*, файдалы катламы — 2 *м* дан 12–15 *м* га кадәр, вак чуерташ 20–50 %. Вак чуерташ һәм ком чыганаклары үзләренең физик-механик күрсәткечләре буенча барлык төр төзелеш эшләренә яраклы. 1991 дән чыганакның тугай өлеше «Түбән Кама» милли паркына карый, өлешчә Алабуга һәм Түбән Кама халкының ял итү урыны буларак файдаланыла.

*Әд.:* Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

*Г.Н.Бирюлёв.*

**ТАНА́Й-ТУРА́Й** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 5 *км* көнчыгыштарак, Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 190 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1646–52 еллардан Турай авылы буларак билгеле. Авыл башта татар морзалары Ишеевлар карамагында була. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 2 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 876,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Ильинка-Шонгат волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 90 ир-ат; 1859 да — 395, 1897 дә — 781, 1908 дә — 905, 1920 дә — 924, 1926 да — 755, 1938 дә — 594, 1949 да — 477, 1958 дә — 414, 1970 тә — 408, 1979 да — 328, 1989 да — 232, 2002 дә — 207 кеше.

**«ТАНДЕ́М» ИНВЕСТИ́ЦИЯ-ТӨЗЕЛЕ́Ш КОМПА́НИЯСЕ»**, акционерлык җәмгыяте. 2002 елда оештырыла. Акционерлары — «Ак Барс капитал» идарәче компаниясе ЖЧҖ һәм «Ак Барс-инвестицияләр» пай инвестицияләренең ябык туры инвестицияләү фонды ышанычлы идарәсе. Эшләүчеләр — 95 кеше. Компания коммерцияле кучемсез милек объектларын төзү, файдалануга тапшыру һәм арендага бирү б-н шөгыльләнә. Гамәлгә ашырылган иң зур проектларының берсе — Идел буенда Европа дәрәҗәсендәге иң эре «Тандем» сәүдә-күңел ачу комплексы (көн саен 27–35 мең кешегә хезмәт күрсәтә). 2005 тә халыкара «Global World Economic Award (GWEA)» җәмәгатьчелек Мактаулы дипломы б-н бүләкләнә. 2008 дә халыкара «Дөнья тәҗрибәсе һәм Россия икътисады» форумы карары б-н «Россиянең иң яхшы 1000 предприятиесе һәм оешмасы» бөтенроссия конкурсында җиңүче дип табыла. 2011 дә Россиянең иң яхшы 100 сәүдә үзәге исемлегенә кертелә. ТР Президентының Рәхмәт хаты б-н бүләкләнә. Җитәкчесе – Ш.Г.Зарифов.

**ТА́НИНО** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 55 *км* көнчыгыштарак, Сушка елгасыннан (Актайның сул кушылдыгы) 3 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 2 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 19 йөзнең 1 нче чирегендә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Крутоямки, Два Озера исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе (1911 дә ачыла), вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 368,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Николо-Пичкас волостенда. 1930 ның 10 августыннан Спас (1935 нең 1 апр. — 1991 нең 4 окт. Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1859 да — 208, 1897 дә — 336, 1908 дә — 353, 1920 дә — 441, 1926 да — 340, 1938 дә — 310, 1949 да — 224, 1958 дә — 255, 1970 тә — 186, 1979 да — 104, 1989 да — 22, 2002 дә — 20 кеше.

**ТАНК КОЛО́ННАЛАРЫ**, 1) халыкның ирекле рәвештә кумәк һәм шәхси иганәләр нигезендә төзелгән хәрби формированиеләр; 2) *Бөек Ватан сугышы* елларында фронтка ярдәм итүнең бөтен халык тарафыннан башкарылу формасы. ТАССРда Т.к. төзүгә акча җыю 3 этапта уза. 1941 елның көзеннән хәрби техника, ш.и. «*Татарстан комсомолы*» Т.к.н төзүгә акча җыела (1942 елның февраленә 2270 мең сум. 1942 нең көзеннән «*Татарстан колхозчысы*» танк колоннасын төзүгә акча җыела (1943 нең башына — 100 млн. сум), 1943 нең язында генерал-лейтенант В.Г.Бурков җитәкчелегендәге 10 нчы танк корпусы сугышчыларына тапшырыла. 1944 тә Кызыл Армиянең Җиңү фондына җыелган акчаның бер өлешенә (1944 нең декабрь уртасында — 62 млн. сум) «Кызыл Татарстан» танк колоннасы төзелә, 1944 нең язында генерал-лейтенант А.О.*Ахманов* җитәкчелегендәге 23 нче танк корпусы сугышчыларына тапшырыла. Сугыш елларында төрле хәрби техника, ш.и. танклар төзүгә респ-ка халкыннан барлыгы 380 млн. сум акча җыела.



Генерал-лейтенант А.О. Ахмановның 23 нче танк корпусына «Кызыл Татарстан» танк колоннасын тапшыру. 1944 елның язы.

*Әд.:* Гильманов З.И. Татарская АССР в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг. К., 1977.

**ТАНКЕ́ЕВКА** (Тәнкәй) авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 23 *км* көньяктарак, Үтәк елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 245 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1710 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богородский исеме б-н дә телгә алына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту, кирпеч сугу һәм тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да Троица чиркәве (1756 да салынган иске чиркәү урынында 1859 да төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1887 дә ачыла), 30 ятак-урынлы участок хастаханәсе, 7 җил тегермәне, 8 кирпеч сугу йорты, 2 тимерче алачыгы, йон тетү бинасы, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1468 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Өчкүл волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас (1935 нең 1 апр. — 1991 нең 4 окт. Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 188 ир-ат; 1859 да — 1009, 1897 дә — 1436, 1908 дә — 1652, 1920 дә — 928, 1926 да — 912, 1938 дә — 825, 1949 да — 713, 1958 дә — 664, 1970 тә — 344, 1979 да — 256, 1989 да — 243, 2002 дә — 256 кеше. Т. янында *Танкеевка комплексы* урнашкан.

**ТАНКЕ́ЕВКА КАБЕРЛЕГЕ́** (археол.), Спас р-ның Танкеевка авылы янындагы 9–10 йөзләргә караган болгар каберлеге. Т.к. *Танкеевка комплексы* составына керә. 1904 елда ачыла (очраклы рәвештә атлы сугышчы кабере табыла). 1960 тан А.Х.Халиков, Е.А.Халикова, Е.П.Казаков һ.б. тарафыннан өйрәнелә. 1200 дән артык кабер ачып тикшерелә. Мәҗүсилек билгеләре булган каберләрдә корбан комплекслары (савытлар, хайван сөякләре һ.б.) табыла. Гадәттә, каберләр озынлыгы 260–300 *см* га, киңлеге 40–60 *см* га, тирәнлеге 220 *см* га кадәр итеп казылган. Мәетләр аркага сузып яткырылган, баш ягы б-н көнбатышка каратылган. Каберләрдә балчык савытлар, агач касәләр, эш кораллары һ.б., махсус камералардагы мәетләрнең аяклары янында — атларның баш һәм гәүдә сөякләре (сугышчы ир-ат каберләрендә әлеге әйберләргә өстәмә — ат дирбиясе һәм сугыш кораллары: кылычлар, уклар, балталар һ.б.) булуы ачыклана; ш.у. кием-салым һәм бизәнү әйберләре: алкалар, муенсалар, асылмалар, беләзекләр, төрледән-төрле бронза һәм көмеш тагылма-бизәмәләр табыла. Идел буе болгарларының һөнәрче түгәрәгендә эшләнгән балчык савыт-сабасы һәм *Салтау-Маяк культурасына* нисбәтле эшләнмәләр б-н бергә әвәләп эшләнгән йомры төпле савытлар, көмеш мәет битлекләре, бронза асылмалар һәм Урал янында яшәүче угор халкына — Полом, Ломоватово һәм Неволино археол. культуралары вәкилләренә хас башка предметлар очрый. Т.к.ндә ш.у. беренче мөселман каберләре дә табыла. Каберлекнең әйберләр комплексы төрле этномәдәни төркемнәрнең



Танкеевка каберлегендә табылган әйберләр: 1. Битлек. Алтын йөгертелгән көмеш; 2. Кувшин; 3. Муенса; 4. Бронза асылма; 5. Көмеш алка һәм бронза асылма; 6. Алтын эшләнмәләр.

үзара йогынтысы, мәҗүсилекнең монотеистик дин б-н алышынуы, ыру-кабилә строеннан дәүләт строена күчү нигезендә болгар халкы формалашуының катлаулы процесслары турында сөйли.

*Әд.:* Генинг В.Ф., Халиков А.Х. Ранние болгары на Волге. М., 1964; Казаков Е.П. Культура ранней Волжской Болгарии. М., 1992; Khalikova E.A., Kazakov E.P. Le cimetiere de Tankeevka // Les anciens hongrois ef elhnies voisines a l'est. Bdpst., 1977.

*Е.П.Казаков.*

**ТАНКЕ́ЕВКА КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Спас р-нының Танкеевка авылы янында урнашкан. Т.к. истәлекләре 19 йөзнең 2 нче яртысында — С.М.Шпилевский, К.И.Новоструев, А.А.Спицин, 1960–70 елларда А.Х.Халиков, Е.А.Халикова, Е.П.Казаков, Г.А.Хлебникова һ.б. тарафыннан өйрәнелә. Күпчелеге Болгар чорына нисбәтле 2 шәһәрлекне һәм 5 авыллыкны (ш.и. Имәнкискә) үз эченә ала. Бронза гасыр керамикасы табыла. Ш.у.к. *Танкеевка каберлеге.*

*Әд.:* Халикова Е.А., Халиков А.Х., Казаков Е.П. Танкеевский могильник // Археологические открытия 1966 года. М., 1967; Хлебникова Г.А., Казаков Е.П. К археологической карте ранней Волжской Булгарии на территории ТАССР // Из археологии Волго-Камья. К., 1976; Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987.

*Е.П.Казаков.*

**ТА́НЬКИНО** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 21 *км* көньяктарак, Ушман елгасы буенда. 2010 елда 43 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1710–11 еллардан Урясь Уча исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Петропавловский, Югары Ураз буларак мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Петропавел чиркәве (1811–22 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1860 та ачыла), фельдшерлык пункты, су тегермәне, йон-тукымаману йорты, 1 казна шәраб һәм 3 вак-төякләр кибете була; пәнҗешәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 607,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 51 ир-ат; 1859 да — 282, 1897 дә — 339, 1908 дә — 387, 1920 дә — 334, 1926 да — 323, 1949 да — 155, 1958 дә — 141, 1970 тә — 118, 1979 да — 101, 1989 да — 61, 2002 дә — 56 кеше.

**ТАНЯ́ЕВ** Александр Петрович (13.4.1898, Мәскәү — 23.11.1974, шунда ук), партия эшлеклесе, тарихчы, тарих фән. д-ры (1927). Коммерция мәктәбен тәмамлаганнан соң (Мәскәү, 1916), Мәскәү ун-тында укый. 1917–19 елларда Мәскәү эшче депутатлар советында инструктор, социаль иминият буенча Мәскәү губерна комиссиясе секретаре, Мәскәү һәм Мәскәү губернасы Берләштерелгән хезмәт бүлегенең оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире. 1919 да Казанга партия эшенә җибәрелә, РКП(б) Казан губерна ком-тының оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире итеп билгеләнә. 1920 дә, ТАССР оешканнан соң, РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре итеп сайлана. ТАССР ҮБК Президиумы әгъзасы. «Вестник Татарского областного комитета РКП(б)» ж-лы мөхәррире. 1921 дән Урта Азиядә партия эшендә, РКП(б)ның Фиргanә өлкә ком-тында агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире. Кызыл профессорлар ин-тын тәмамлаганнан соң (Мәскәү, 1924), Свердловск шәһәрендә эшли, Урал-Себер коммунистлар ун-тында проф. (1928 дән); ВКП(б)ның Урал өлкә ком-тында инструктор, Урал-Казакъстан сәнәгать академиясе директоры. 1934–37 дә Мәскәүдә, СССР әдәбият һәм нәшриятлар эше буенча баш идарә башлыгы урынбасары. 1937 дә репрессияләнә; 1956 да аклана. Эшчеләр хәрәкәте һәм Гражданнар сугышы тарихына, А.И.*Догадовка* багышланган хезмәтләр авторы.

Хезм.: Очерки движения железнодорожников в революцию 1917 г. (февраль–октябрь). М.–Л., 1925; Колчаковщина на Урале (1918–1919 гг.). Свердловск–М., 1930; Рабочее движение на Урале в годы империалистической войны. Свердловск–М., 1931.


*Әд.:* Мусин М. Таняев Александр Петрович // Борцы за счастье народное. К., 1967.

**«ТАҢ»**, иҗтимагый-сәяси газета. 1918–22 елларда Сембер шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. РКП(б)ның Сембер губерна ком-ты карамагындагы татар секциясе һәм милләтләр эшләре буенча губерна бүлеге каршындагы татар бүлекчәсе органы. 1918 нең ноябреннән 1919 ның 24 маена кадәр, Сембер губернасы башкарма ком-ты каршындагы рус булмаган халыклар эшләре буенча бүлек органы буларак, «Көн» исеме б-н дөнья күрә, барысы 41 саны чыга. 1919 ның 19 июненнән исеме «Таң» итеп үзгәртелә (118 сан). Мөхәрририяткә Ш.Измайлов, Л.Мәҗит, Р.Мозаффаров керә. Сембер төбәге б-н бәйле булган проблемалар һәм вакыйгаларга зур игътибар бирелә. Предприятиеләр, сәламәтлек саклау органнары эшен җайга салу, ачлык б-н көрәшү мәсьәләләре күтәрелә. Хатын-кызларны иҗтимагый эшкә җәлеп итү темасы зур урын алып тора. 1920 нең 1 ноябрь саны тулаүсез кушымта — «Безнең партия» брошюрасы б-н чыга.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом) 1905–1925. К., 1926; Гайнанов Р.Р., Марданов Р.Ф., Шакуров Ф.Н. Татарская периодическая печать (1905–1924): Библиогр. указ. К., 1999.

**«ТАҢ»**, Менделеев шәһәрендәге җамигъ мәчет. 1995 елда арх. Ф.Р.Закиров проекты буенча төзелә. Ике катлы, ике заллы, ишекләре һәм заллары ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен аерым. Мәчет ишекләре планда турыпочмаклы мәчет бинасының төньяк почмагындагы җир өстеннән күтәрелгән, сигез кырлы гөмбәз б-н очланган өч ярусылы манараның түбән ярусында, көнбатыш һәм көнчыгыш якларга урнашкан. Беренче катта — ике маршлы ике баскыч урнаштырылган зур вестибюль. Хатын-кызлар өчен намаз залы аскы катның көньяк өлешендә. Икенче катны ир-атлар өчен билгеләнгән намаз залы били, аның көньягында михраб куышы, төньягында манара ишеге уелган. Ир-атлар залына ш.у. ишегалдыннан манараның түбән ярусы аша үтәргә мөмкин. Манараның төньяк дивары тышындагы баскыч подвал катына илтә. Мәчетнең түбә кыегы тасма пыялалы яктылык барабанындагы сигезкырлы гөмбәз б-н очланган. Зал интерьерына ачылган гөмбәз кв. кисемле 4 колоннага таянган. Залның гөмбәз астындагы иң биек урыны — 15 *м.* Манара баскычлы-ярусы корылмадан гыйбарәт. Бе-

ренче ярусның биеклеге мәчет күләменең нигезе б-н бертигез. Бормалы баскычлы сигезкырлы икенче ярус 17,5 *м* биеклектә, анда фонарь б-н яктыртылган түгәрәк мәәзәнә урнашкан. Биек, тар тәрәзәле манараны очына шарлы ай беркетелгән нәфис чатыр каплый. Мәчетнең буй фасадлары өч яссы ризалит



Менделеев шәһәрендәге «Таң» мәчете. Архитекторы Ф.Р. Закиров. 1995.

б-н ныгытылган һәм ике кыеклы түбә б-н ябылган. Зур тәрәзәләр ризалитлар куышына батырылган. Беренче кат биналары, төп күләмнең ян фасадлары, михраб һәм манараның аскы ярусы П-рәвешле тасма тәрәзәләр б-н яктыртылган. Бинаның барлык почмаклары стильләштерелгән сигезкырлы гөмбәзе алтын йөгертелгән шарлы ай б-н тәгәлләнгән. Мәчетнең төсләр чишелеше аксыл-көрән (диварлар), кызгылт-көрән (ризалит куышлары), көмешсыман (гөмбәз, чатыр һәм манара мәәзәнәсе) һәм айның алтынсу төсләре б-н аралаштыруга корылган.

*Әд.:* Мечети Татарстана // Сост. Х.Г.Надырова, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хайрутдинов. К., 2000.

*Х.Г.Надыйрова.*

**«ТАҢ»**, Лаеш р-ның Имәнкискә авылы крәстияннәр хуҗалыгы. 1997 елда элеккеге Крәстиян кооператив хуҗалыклары ассоциациясе терр-ясендә оештырыла (1992 гә кадәр «Маяк» к-зы). А.х. җитештерүендә 31 кеше эшли. 2009 да 900 *га* а.х. файдалану җирләре (ш.и. 51 *га* үз җирләре, 849 *га* аренда җирләре), 20,1 мең башка исәпләнгән бытбылдык йомыркасы җитештерү фермасы була. Хуҗалыкның төп тармагы — бөртекле ашлык һәм бытбылдык йомыркасы җитештерү. 1750 *т* бөртекле ашлык, 2 млн. 307 мең данә йомырка җитештерелгән. Бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 28,2 *ц* тәшкил итә. Хуҗалык башлыгы — Р.Я.Галиев (1997 дән).

**«ТАҢ»**, Мамадыш р-нындагы а.х. пр-тиесе. 1969 елда «Чулпан» к-зы җирлегендә оештырыла. 1993 тән кумәк а.х. пр-тиесе, 2002 дән агрофирма, 2005 тә «Нократ» агрофирмасына кушыла. Составына Комазан Башы, Малмыж, Акман, Яковка, Дүсмәт (үзәк утары) авыллары керә; 436 хуҗалык. Төп тармагы — сөт җитештерү. А.х. файдалану җирләренең мәйданы 4726 *га* (ш.и. сөрүлек җирләр 3378 *га*). Мөгезле эре терлек — 2,5 мең баш, ш.и. 650 баш сыер (1993). Еллык савым һәр сыердан — уртача 4505 *кг*. 100 *га* файдалану җирләренә күчереп исәпләгәндә, 620 *ц* сөт, 68,4 *ц* ит җитештерелә. «Чулпан» к-зы СССР ВДНХсы дипломнары (1980, 1983, 1985), КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКларының истәлекле Кызыл байрагы һәм Мактау грамоталары б-н бүләкләнә (1982, 1990). Хуҗалык үсешенә З.Ш.*Һадиуллин* зур өлеш кертә (1965–95).

*И.Н.Афанасьев.*

**«ТАҢ»**, борчак сорты. 1998 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында Т.Г.*Евдокимова*, А.Н.*Фадеева*, И.П.Еряшева тарафыннан чыгарыла. Сорт уртача өлгерешле, вегетация чоры 72–78 көн. Сабагы сөрлегүчән. Үсемлекнең буе 75–110 *см*. Кузаклары туры, 6 *см* га кадәр озынлыкта, 4–6, иң күбе 8 орлыклы, ал төстә, түгәрәк формада; 1000 бөртекнең авырлыгы 230–260 *г*. Азык сыйфатлары яхшы, пешү вакыты уртача. Коелуга һәм корылыкка чыдамлыгы югары. Кыяклы культуралар б-н катнаш чәчүгә яраклы. Авыруларга чыдамлыгы уртача. Уңышы 1 *га* дан 50 *ц* га җитә. РФнең Урта Идел (ш.и. ТР) һәм Үзәк регионнары буенча Селекция казанышлары дәүләт реестрына кертелгән (2001). ТРда уңышы — 1 *га* дан 25 *ц*.

*Әд.:* Каталог научно-технической продукции. К., 2005.

**«ТАҢ ЙОЛДЫЗЫ́»**, газета. Татар эсерлары — «*Таңчылар*» оешмасы органы. 1906 елның 18 маеннан 16 ноябренә кадәр Казанда татар телендә атнага 2–3 тапкыр нәшер ителә, барысы 65 саны чыга. Нашире — Г.Путиләков, аннары — Ф.*Туктаров*, мөхәррире — Г.Путиләков, 19 июньнән С.*Рәмиев*, фактик мөхәррире — Г.*Исхакый*. «Белем — фикерләүгә ачкыч һәм бәхеткә баскыч» девизы б-н чыга. «Т.й.»ның максаты — хезмәт ияләре мәнфәгатьләрен яклау. Сәяси мәсьәләләргә: мөселман депутатларының Дәүләт Думасындагы эшчәнлегенә, соц. идеяләрне пропагандалауга зур игътибар бирелә. Редакция татар либераль демократларының принципиаль оппоненты, татарларның милли, сәяси һәм рухи мөстәкыйльлеген яклаучы булып тора, Учредительләр җыенын чакыруны яклап чыгыш ясый. Күп кенә мәкаләләрдә «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясенең программасы тәнкыйтьләнә. Г.Исхакый газетаны үз трибунасы сыйфатында файдалана («Чыңгыз», «Япанчы» псевд. б-н басыла). «Т.й.» битләрендә аның Ф.*Кәрими* б-н шәхси каршылыклы мөнәсәбәтләре чагылыш таба. С.Рәмиев килү б-н, газетаның сәяси юнәлеше көчәя, дәүләт структурасын тәнкыйтьләгән мәкаләләр саны арта; Рәмиевнең анда басылган шигъри әсәрләрендә консерватив руханилардан мыскыллап көлү, милләтнең үсешенә һәм аң-белемгә чакыру яңгырый. Басма авторларының сәяси радикализмы татар мәдәниятенә, әдәбиятына, теленә багышланган материалларда, татар язучылары китапларына һәм татар театрлары спектакльләренә рецензияләрдә, татар матбугатына күзәтүләрдә күренә. «Т.й.»ндагы мәкаләләрнең хөкүмәткә кискен каршы рухта булуы хөкүмәтнең игътибарыннан читтә калмый. Аның дистәгә якын саны конфискацияләнә. Ышанычсыз басма буларак, газета ябыла. «Таң мәҗмугасы» ж-л-җыентыгы итеп үзгәртелә: ике саны (1906 ның 18 декабре, 1907 нең 1 июле) конфискацияләнә; рәсми мөхәррир-нашире — Х.Әбүзәров, фактик мөхәррире Г.Исхакый була. «Таң йолдызы»ның дәвамчысы — «*Тавыш*» г-тасы.



«Таң йолдызы» газетасы.

*Әд.:* Ф а х р у т д и н о в Р.Р. Татарский либерализм в конце XIX — начале XX вв. К., 1998.

**«ТАҢ МӘҖМУГАСЫ́»**, к. «*Таң йолдызы*».

**«ТАҢБАТЫ́Р»**, тылсымлы татар халык әкияте. Традицион сюжетка нигезләнгән: ярлы карт б-н карчыкның уллары Кичбатыр, Төнбатыр һәм Таңбатыр урланган өч патша кызын эзләргә чыгалар. Карт б-н карчыкның иң көчле һәм кыю кече уллары Таңбатыр төп рольне башкара. Ул җир асты патшалыгына төшә һәм, өч *диюне* үтереп, патша кызларын коткара. Бик күп маҗаралардан соң герой патша кызларының кечесенә өйләнә һәм патша була. Әкияткә традицион мотивлар һәм символлар хас: чибәр кызларны урлау һәм эзләү, җир асты патшалыгындагы сынаулар, теге һәм бу дөньяны үзара бәйләп тора торган кое, инициация йоласы аналогы — *Убырлы карчыкның* геройны йотуы һәм төкереп чыгаруы, ахырдан геройның җиңүе.

Әкиятнең бер вариантын 1950 елда Ютазы р-ның Бәйрәкә авылында Х.Х.Ярмөхәммәтов (Х.Х.Ярми), икенчесен 1954 тә Биектау р-ның Олы Кавал авылында И.Н.Надыйров язып ала. Алар «Татар халык әкиятләре» җыентыгында басылып чыга (1956). Кулъязмалар ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының фольклор фондында саклана.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1977. 1 кит.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ТАҢГАЛЫ́ЧЕВ** Камил Абидулла улы (1.2.1968, Мордва АССРның Ельник р-ны, Күгеш а.), язучы, Мордва Респ-касының атказ. язучысы (2005). Рус телендә яза. Саранск шәһәрендә яши. Мордва пед. ин-тын тәмамлый (1990). 1995 елдан «Трибуна колхозника», «Советская Мордовия», «Мордовия», «Учитель», «Мордовия — 7 дней» г-талары редакцияләрендә эшли. 2006 дан РФ Федераль Җыенының «Парламентская газета» күзәтчесе. Саранскида басылып чыккан

«Миләш кыңгыраулары» («Рябиновые бубенцы», 1992), «Мине җитәкләп йөртүче» («Мой поводырь», 1998), «Иң якын авыл» («Ближняя деревня», 2001), «Казанга юл» («Дорога в Казань», 2002), «Яттан» («Наизусть», 2007) шигъри җыентыклар, «Айлы алачык» («Лунная мастерская», 1999), «Киләчәк җир» («Грядущая земля», 2000), «Табигать көчләре» («Стихия», 2004), «Тигәнәк җиләге» («Ягода репейника», 2006) эссе җыентыклары авторы. Т. әсәрләре, татарчага тәрҗемә ителеп, «Казан утлары», «Идел» ж-лларында, «Татарский мир», «Мәдәни җомга» г-таларында басыла. Т. поэзиясенә сәнгати нечкәлек, фәлсәфи тирәнлек, классик язу манерасының үзара үрелеп баруы хас. Прозасы әйләнә-тирәгә поэтик карашы б-н аерылып тора.

Ә с ә р.: Избранное. Саранск, 2006.

*Әд.:* Х а р и с Р. Возвращение по Казанской дороге: О стихах Камиля Тангалычева // Казань. 2007. № 1. *Р.Р.Мусабәкова.*

**ТАҢЧУЛА́КОВ** Йосыфбәк Шәйхелислам угылы (1857–1936), шагыйрь. Казакъ һәм татар телләрендә язган. Китап һәм фольклор традицияләрендә язылган героик-романтик һәм фантастик поэма-риваятьләр, ш.и. романтик мәхәббәт характерындагы «Кыйсса-и Сәйфелмөлек» (1876) дастаны версиясе авторы. Әсәр сюжеты «Мең дә бер кичә» җыентыгына кайтып кала. Аңа нигезләнеп, 15 йөз ахыры — 16 йөз башында шагыйрь *Мәҗлиси* шул ук исемдә дастан яза (беренче тапкыр Казанда 1807 елда басыла, күп тапкыр кабат басыла).


*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. 1 том.

**ТАҢЧЫЛА́Р**, татар эсерлары оешмасы. Исемен басма органнан — *«Таң йолдызы»* г-тасыннан ала. 1905 елда Казанда *социалист-революционерлар партиясе* йогынтысындагы Идел буе ком-ты буларак кискен карашлы татар яшьләре тарафыннан оештырыла. Башлап йөрүчеләре: Г.*Исхакый*, Ф.*Туктаров*, Ш.*Мөхәммәдьяров*; актив әгъзалары: Х.Әбүзәров, С.Рәмиев, Ф.Сәйфи-Казанлы. Пропаганда һәм нәшрият эшчәнлеге б-н шөгыльләнәләр, патша хакимиятен бәреп төшерүне, Учредительләр җыенын чакыруны таләп итәләр. Оешма әгъзалары, «Хөррият» исемендә гектографик г-та чыгару тәҗрибәсе булганлыктан, «Таң йолдызы», «Таң мәҗмугасы», *«Тавыш»* исемле легаль г-талар чыгаруны да җайга салалар. Алар соц. идеяләр тарафдарлары, татар халкының этносәяси һәм этномәдәни мәнфәгатьләрен, аның милли һәм рухи мөстәкыйльлеген яклау тарафдарлары булалар. Дәүләт Думасына сайлауларда актив катнашып, татар эсерлары 2 нче Думада *«Мөселман хезмәт таифәсе»*н оештыралар. Җитәкчесе — Ф.Туктаров. 1907 дә, җитәкчеләре кулга алынгач, төркем таркала.

*Әд.:* А м и р х а н о в Р.У. Татарский народ и Татарстан в начале XX в. К., 2005; Ислам на европейском Востоке: Энцикл. словарь. К., 2004.

**ТАҢШИРМӘ́**, к. *Тоншерма*, Тәтеш р-ны.

**ТА́ПИКОВ** Самуил Михайлович (1.11.1915, Уфа губ., Минзәлә өязе Яңа Мәлкән а. — 5.2.1945, Эльбинг ш., Польша), Сов. Союзы Герое (29.6.1945, үлгәннән соң), капитан. Ленинград артиллерия уч-щесен тәмамлый (1938). Казанда яши һәм эшли. 1934–35 елларда һәм 1941 дән Кызыл Армиядә. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 398 нче җиңел артиллерия полкының (65 нче армиянең 18 нче артиллерия дивизиясенең 65 нче җиңел артиллерия бригадасы) дивизион командиры. Дон, Үзәк, 1 нче һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Сталинград (1942–43), Курск (1943) сугышларында, Чернигов-Припять, Гомель-Речица (икесе дә — 1943), Белоруссия (1944) һәм Көнчыгыш Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Эльбинг тирәсендә Висла елгасы аша чыкканда батырлык күрсәтә: 1945 нең 5 февралендә, контрһөҗүмнәрне кире кайтарганда батареялар уты б-н оста идарә итеп, дошманның тере көчләрен һәм хәрби техникасын зур югалтуларга дучар итә, сугышта һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Байрак, Александр Невский орденнары, медаль б-н бүләкләнә. Минзәлә шәһәрендәге бер урам Т. исемен йөртә.



С.М.Тапиков.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

**«ТАПКЫ́Р КЫЗ»**, татар халкының тормыш-көнкүреш әкияте. Вариантларының берсе «Утынчы карт» исемендә. Сюжеты күп халыкларның фольклорында киң таралган. Әкият тексты тулысынча сүз уйнатуга нигезләнгән. Утынчы карт базарда утын сата. Берзаман аны хәйләкәр бай алдый. «Бөтенесен дә сатасыңмы?» — дигән сорауга карт: «Әйе», — дип җавап бирә, һәм бай утыны б-н бергә картның арбасын да алып китә. Икенче вакыт атасы урынына базарга картның тапкыр кызы килә. Шул ук байдан акча алганда ул: «Үз кулың белән бирәсеңме?» — дип сорый. Бай аңа: «Әйе», — ди. Шуңа таянып (татар телендә сүз уйнату: «кул белән бергә»), кыз байның кулы хәзер аныкы булуын, бай кулын кисеп аңа бирергә тиешлеген әйтә. Кызның хаклыгын казый да раслый. Килеп туган хәлдән чыгу юлларын эзләп, бай б-н кыз бәхәскә керә. Әгәр кыз аны алдый алса, бай аңа 2 мең сум акча бирәчәк. Тапкыр кыз байны әтисенең үлемендә гаепли. Бай чарасыз кала (әгәр кызның сүзен рsitu расласа, аны үтерүче дип таныячаклар). Шулай итеп, үзенең тапкырлыгы аркасында кыз үгез б-н арба бәясен кире кайтара. Әкиятнең берничә варианты бар. 1939 елда Теләче р-нының Максабаш авылында Г.Бәширов язып ала. Беренче тапкыр «Халык әкиятләре» китабында басылып чыга (1940). «Утынчы карт» вариантын 1974 тә Кама Тамагы р-нының Олы Яңасала авылында Л.Ш.Җамалетдинов язып ала. Кулъязмалар ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының фольклор фондында саклана.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1981. 3 кит.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ТАПП**, к. *Татар пролетар язучылары ассоциациясе.*

**ТАРАБА́РИН** Олег Игоревич (5.7.1950, Чаллы ш.), техник системаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2004), проф. (2005). 1972 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1981 дән Кама инженерлык-икътисад академиясендә (Чаллы ш.), машиналар төзү технологиясе, металл кисү станоклары һәм инструментлары каф. профессоры (2005 тән). Хезмәтләре нефть-газ җиһазларының куркынычсызлыгын тәэмин итүгә карый. Т. җиһазларны эксплуатацияләү мөмкинлекләрен исәпләү алымнарын, хәвеф-хәтәрсез эшләүне тәэмин итү буенча норматив документлар комплексын эшли.

Х е з м.: Кинетика механо-химического разрушения. М., 1996 (автордаш); Оценка предельных параметров заготовок в условиях монтажа оборудования. Наб. Челны, 2003; Формирование ресурса оборудования при монтаже. М., 2003.

**ТАРАКАНСЫМАННА́Р** (Blattoptera), бөҗәкләр отряды. Ташкүмер чорыннан билгеле; җир кабыгының башка катламнарында күп. Россиядә 50 дән артык төре билгеле. Озынлыгы 4 тән 95 *мм* га кадәр. Гәүдәсе яссы, башы өске яктан зур сырт б-н капланган, мыеклары кылсыман, 5 буынтыклы аяклары йөгерүгә җайлашкан, корсагы церкалар б-н тәмамлана. Алгы канатлары канат өслегенә әйләнгән. Ата затларның корсагында ис бизләре урнашкан. Т. — күбесенчә яшерен яшәү рәвеше алып баручы төнге бөҗәкләр, коелган яфрак, таш астында, кайвакыт туфракта, җылы биналарда һ.б.да яшиләр. Күкәйләрен махсус капсулаларда — оотекаларда салалар. Үсеше 2–3 айдан 3–4 елга кадәр бара. Талымсызлар (төрле азык б-н тукланучылар), органик калдыклар б-н тукланалар. Җирән таракан (Blattella germanica), кара таракан (Blatta orientalis), Америка тараканы (Periplaneta americana) Җир шарында киң таралганнар, кеше торакларында яшиләр, азык продуктларын, китап тышлыкларын, бүлмә гөлләрен һ.б.ны зарарлыйлар, дизентерия, суалчан һ.б. авыруларны таратучылар. Татарстан терр-ясендә, синантроп төрләрдән тыш, урманнарда еш кына Лапландия тараканы (Ectobius copponicus) очрый.

*С.М.Шәфигуллина.*

**ТАРАСЕ́ВИЧ** Станислав Эдуардович (4.1.1955, Үзбәкстан ССРның Сәмәрканд ш.), термофизик, техник фән. д-ры (1997), проф. (2001). 1978 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1998–2005 тә җылылык физикасының теоретик нигезләре каф. профессоры, 2007 дән Авиация, җир өсте транспорты һәм энергетика ин-ты директоры. 2005–07 дә ТРның мәгариф һәм фән министры урынбасары. Хезмәтләре эчке дисперс агымнарның җылылык һәм масса алмашына, масса көчләре кырларында бер яки ике фазалы агымнарның җылылык алмашына һәм гидродинамикасына карый. Т. термоэнергетик җиһаз каналларында төрле көчәйткечләр (агымны бору, өслекнең кытыршылы-

гы) кулланылган күптөрле җылылык йөрткечләр (ш.и. криоген) агышында җылылык алмашу процессы һәм гидродинамика законнарын билгеләгән. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Гидродинамическая теория кипения Кутателадзе С.С. и кипение криогенных жидкостей в полях массовых сил // Изв. РАН. Энергетика. 1996. № 2; Теплоотдача турбулентного потока на шероховатой поверхности в условиях ускорения и вдува // Изв. вузов. Авиац. техника. 1999. № 3 (автордаш); Теплообмен в кольцевых каналах с закруткой потока // Изв. вузов. Авиац. техника. 2007. № 3 (автордаш).

**ТАРА́СОВ** Валерий Фёдорович (21.6.1947, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (2002), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1971 дән РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында, директор урынбасары (1992 дән). Хезмәтләре магнит радиоспектроскопиясенең экспериментал алымнарына һәм аларны диэлектрик кристалларның магнит үзлекләрен өйрәнүдә куллануга карый. Т. акустик һәм электромагнит импульслар кушылмалары тудыра торган төш-спин кайтавазын беренче булып экспериментта күзәтә (1975). Синтетик форстерит кристалларында катышма гольмий ионнарының үзлегеннән димерларга молекуляр оешуы күренешен аңлата, ике валентлы хромның катышмалы үзәкләре структурасын һәм магнит үзлекләрен билгели. Көчле акустик дулкын кырында төш спиннары квантлашу күренешен ачыклый. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Акустическое возбуждение ядерного спинового эха // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1975. Т. 22, вып. 5 (автордаш); ЭПР ионов хрома в синтетическом форстерите в субмиллиметровом диапазоне // Физика твёрдого тела. 1995. Т. 37, вып. 2 (автордаш); Молекулярная самоорганизация примесных ионов $Ho^{3+}$ в синтетическом форстерите // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 2003. Т. 77, вып. 11 (автордаш).

**ТАРА́СОВ** Геннадий Сергеевич (19.3.1946, Казан — 1.8.2005, шунда ук), спортчы, тренер (тимераякта фигуралы шуу), РСФСРның атказ. тренеры (1980). Пермь пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1976). РСФСР чемпионатында медаль ала (Идел буе зонасы; 1971), РСФСР, СССР халыклары спартакиадаларында катнаша (1971). 1969 елдан тимераякта фигуралы шуу буенча Респ-ка махсуслаштырылган Олимпия резервындагы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тренер (Казан), бер үк вакытта, 1976–80 дә, СССР җыелма һәм Олимпия (1979) командаларында тренер. Шәкертләре арасында — А.В.*Фадеев*, Европа (1984, 1986–87), дөнья (1985) чемпионы, Олимпия уеннарында ялгыз шуу буенча катнаша (1984).

**ТАРА́СОВ** Леонид Андреевич (20.8.1939, Украина ССРның Киев өлкәсе Белая Церковь ш.), химик-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997), химия фән. канд. (1969), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1961 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, оборона пр-тиесендә эшли. 1966 дан Казан химия фәнни-тикшеренү ин-тында, сектор башлыгы (1973 тән), лаб. башлыгы — хезмәтне саклау һәм аның куркынычсызлыгы үзәге директоры урынбасары (2000 нән). Хезмәтләре фениофосфин к-тасы моноэфирының натрий тозлары б-н кайбер хлорлы кушылмалар реакциясенә, көчеш металларының ферроцианидлар классын тикшерүгә карый. Т. изоляция һәм фильтрлаучы тибындагы саклагыч тукымалар һәм өс киеме комплектларын эшли (ТР һәм БДБ пр-тиеләренә җибәрелә). Дәүләт бүләге җитештерүдә һәм һәлакәт очракларындагы агулы, агрессив матдәләр һәм җылылык факторлары тәэсиреннән кешене комплекслы саклау системасын эшләүдә һәм сериялап чыгаруда катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 21 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О взаимодействии b-хлорэтилового эфира с натриевыми солями моноэфиров фенилфосфинистой кислоты // Журн. орган. химии. 1969. Т. 39, вып. 2; Модифицированные хемсорбционные волокна на основе сополимера акрилонитрила с 5-винил-2-метилпиридином // Хим. волокна. 1988. № 1 (автордаш); Фильтрующая защитная одежда // Безопасность труда в промышленности. 1992. № 9 (автордаш).

**ТАРА́СОВА** Наталья Борисовна (4.1.1957, Апас р-ны Апас а.), радиобиолог, биол. фән. д-ры (2007). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1987), Хайваннарның токсикологик һәм радиацион куркынычсызлыгы буенча федераль үзәкнең (Казан) радиобиол. бүлегендә эшли, 2007 елдан радиация контроле һәм техника лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре изотоплы гамма-җайланмаларда радиацион зыян очракларын модельләштерүгә, хайваннарда икенчел иммунодефицит, кушылма: радиацион һәм химик зыян очракларында дәвалау һәм бу авыруларны кисәтү чаралары һәм ысулларын эшләүгә карый. Уйлап табуга 4 патенты бар.

Х е з м.: Проблемы радиоэкологии и биологически активные вещества // Материалы междунар. конф., посвящ. 25-летию Чернобыльской катастрофы «Современная экологоантропологическая методология изучения и решения проблем здоровья населения». К., 2011 (автордаш); Перспективы применения лечебнопрофилактического иммуноглобулина в ветеринарии // Международный вестник ветеринарии. 2011. № 1 (автордаш); Содержание общего белка и белковых фракций в сыворотке крови лошадей-доноров, используемых при получении противорадиационных препаратов // Веткорм. 2013. № 6 (автордаш).

**ТАРА́СОВА** Татьяна Ивановна (6.1.1965, Әлмәт ш.), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2012). Мәскәү нефть һәм газ ин-тын тәмамлаганнан соң (1990), ТатНИПИнефтьтә, эзләү һәм разведкалау геологиясе башлыгы урынбасары (2006 дан). Дәүләт бүләге «Татнефть» АҖнең ресурслар базасын үстерүдәге алымнар һәм технологияләрнең фәнни нигезләре һәм аны сәнәгый кулланышка кертү» хезмәтендә катнашуы өчен бирелә.

**ТАРАЯКЛЫ́ КЫСЛА́** [Astacus (Pontastacus) leptodactylus], кысласыманнар классындагы тереклек иясе. Төче сулыкларда яши. Татарстан терр-ясе, аеруча чиста сулы Куйбышев сусаклагычы, зур күлләр һәм елгалар өчен гадәти төр. 20 йөз башында Т.к. Идел елгасы бассейнының югары агымында тарала һәм киңаяклы кысланы (Astacus astacus) кысрыклап чыгара, хәзерге вакытта исә аның ареалы Балтыйк диңгезе бассейны б-н чикләнә. Т.к.ның озынлыгы 15 *см* га җитә. Башкүкрәк калканы яки каты хитин япма барлык 8 күкрәк сегменты б-н дә тоташып үскән. Күзләре парлы, сабакчыкларда урнашкан. Ике пар мыекчыгы сизү функциясен үти. Корсагы хәрәкәтчел тоташкан 6 сегменттан тора, аларда буынтыклы аяклар урнашкан. Кыскычлары көчле, алга карап тора, азыкны эләктереп алырга һәм кисәкләргә бүлгәләргә җайлашкан. Күкрәк аяклары төрле функцияне башкара, ш.и. йөрү өчен хезмәт итә. Аяклары янында ук саңаклар урнашкан, корсагының арткы өлешендә койрык йөзгече бар, аның ярдәмендә Т.к. гәүдәсенең арты б-н алга таба тиз хәрәкәтләнергә сәләтле. Нигездә, төнлә активлар. Төрле азык б-н, тере, ш.у. үлгән хайваннар, су үсемлекләре б-н туклана. Аерым җенесле. Әчке аталану хас. Ана зат күкәйләрне корсагының астында йөртә. Кабык салу чорында Т.к. яңа кутикуласы катыланганчы үсә. Кайвакыт күпләп кысла чумасыннан үләләр. Т.к. — кыйммәтле азык-төлек продукты, чиста су индикаторы. ТРның Кызыл Китабына кертелгән.

*Әд.* к. *Кысласыманнар* мәкаләсен.

*В.А.Яковлев.*

**ТАРИКА́ТЬ**, к. *Суфичылык.*

**ТАРИ́Х**, 1) табигать һәм җәмгыять үсеше процессы; 2) аларның үткәнен өйрәнүче фәннәр комплексы.

Т. фәне — иҗтимагый фәннәр төркеменең бер өлеше. Т.ның өйрәнү объекты — үткәндә һәм хәзерге заманда җәмгыять тормышын чагылдыручы барлык фактлар җыелмасы. Т. фәне аерым бүлекләрдән һәм тармаклардан тора. Беренче төркемгә җәмгыять тарихын гомуми (бөтендөнья Т.ы) һәм аның аерым якларын (борынгы җәмгыять Т.ы, урта гасырлар Т.ы, Алтын Урда Т.ы, Россия Т.ы, икътисади Т., хәрби Т. һ.б.) өйрәнүче бүлекләр һәм тармаклар керә; икенче төркемне ярдәмче Т. фәннәре (мәс., генеалогия, *геральдика, нумизматика,* хронология, метрология) тәшкил итә.

Казан төбәгендә Т.ның фән буларак үсеше *Идел буе Болгар дәүләте* барлыкка килгән вакыттан башлана. Болгарларның тарихи күзаллаулары турында мәгълүмат аз, безнең көннәргә килеп җиткән *әл-Гарнати, Ибне Рустә, Ибне Фазлан, Ибне әл-Әсир* һәм кайбер башка авторлар, ш.у. татар фольклоры әсәрләрендә генә тулы булмаган мәгълүматлар сакланган. Идел буе Болгар дәүләтендә рәсми дин сыйфатында ислам дине кабул ителү (922), Көнчыгыш мөселман илләре б-н сәүдә-икътисад, дини һәм мәдәни бәйләнешләр мәгариф, мәдәният һәм фән үсешенә китерә. Идел буе Болгар дәүләтендә болгарларның килеп чыгышы турында фикерләр формалаша һәм тарала. Болгар халкының тарихи карашларына борынгы төрки мифология, риваятьләр, ш.у. гарәп һәм фарсы галимнәренең дини хезмәтләре зур йогынты ясый. 11–12 йөзләрдә болгарларның үз тарихи мәктәбе формалаша башлый, *Ягъкуб бине Ногман*

шуның бер вәкиле була. Алтын Урдада Т. фәне үсешен дәвам итә һәм ш.у. мөселман Шәрегы тарихи традицияләренең көчле йогынтысында була. Гарәп авторлары *Ибне Баттута*, Ибне Хәлдун, Ибне әл-Вәрди һ.б. хезмәтләрендә күрсәтелгәнчә, Алтын Урда башкаласы Сарай әл-Мәхруса шәһәрендә бик күп галимнәр, ш.и. тарихчылар яши һәм эшли (билгеле булганнары: Мохтар ибне Мәхмүд әз-Заһидинең Бәркә хан турында әсәр язуы мәгълүм, *Сәйф Сараи* – «Китабе Гөлестан бит-төрки» әсәре авторы, анда тарихи-фәлсәфи, иҗтимагый-дини һәм әхлакый-этик темага фикерләр тупланган). Алтын Урда таркалганнан соң (1430–40 еллар), Т. фәне үсеше татар ханлыкларында (Казан, Касыйм, Әстерхан, Себер ханлыкларында) дәвам итә. *Казан ханлыгы* Т.ы буенча чыганаклар сугышлар, баш күтәрүләр, янгыннар вакытында шактый күләмдә югалалар. Кайбер мәгълүматлар аерым генеалогияләрдә һәм фольклор традицияләрендә (*«Дәфтәре Чыңгызнамә»*, *Кадыйргали бәкнең* «Елъязмалар җыентыгы») саклана, бу тарихи традицияләрнең күчемлелеге хакында фаразларга нигез бирә. Татар халкы Т.ының аерым аспектлары *Мөхәммәдьярның* «Төхфәи Мәрдан» (1539–40), «Нуры содур» (1542) поэмаларында, Шәрифи Хаҗитарханинең «Зафәрнамә-и вилайәти Казан» әсәрендә, ш.у. аноним авторның «Казан елъязмачысы»нда («Казанский летописец») чагыла. 1552 дә дәүләтчелекне югалту, татар ханлыкларының яулануы тарихи белемнәр үсешенә күп кенә үзгәрешләр кертә: идарәчеләр, династияләр һәм дәүләтләр Т.ын төзү традицияләре югала. *Шәҗәрәләр* төзү һәм кабер ташъязмалары традициясе саклана, аларның кайберләрендә Чыңгыз хан, Аксак Тимер, Идегәй һ.б. нәселләре турында мәгълүматлар бар. 16 йөзнең 2 нче яртысыннан төбәк терр-ясендә Россия Т.ы фәне үсеше башлана.

18 йөздә төбәк Т.ын өйрәнү күбесенчә С.-Петербург галимнәре тарафыннан алып барыла (к. *Академия экспедицияләре*). 1758 дә ачылган *Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе* Көнчыгышны өйрәнүчеләрне әзерләү өчен җирлек булып тора. 1804 тә Казан ун-ты ачылуга, анда Россия дәүләте Т.ы, статистикасы һәм географиясе каф. һәм *Шәрекъ бүлеге* оештырылу б-н (соңгысы *шәркыять гыйлеме* үсешенә нигез сала), төбәк турындагы тарихи белемнәр үсешендә яңа этап башлана. Төркология, монголларны, кытайларны, гарәпләрне өйрәнү буенча И.Н.*Березин*, В.П.*Васильев*, О.М.*Ковалевский*, М.К.*Казимбәк*, П.Я.*Петров*, И.Н.*Холмогоров*, Х.М.*Френ* хезмәтләре гомумроссия күләмендә генә түгел, Европа күләмендә танылa. Университет галимнәре төбәк һәм татар халкы Т.ын актив өйрәнәләр; аларның хезмәтләре *татар халкын өйрәнү гыйлеме* (Х.*Фәезханов*, Ф.И.*Эрдман*, И.Н.Березин, К.Ф.*Фукс* һ.б.) формалашуга ярдәм итә. 1820 елларда тарихи *төбәкчелек белеме* формалаша. 1829 да Н.И.Лобачевский башлангычында оештырылган «Казан фәннәр җәмгыяте» губернада беренче төбәкне өйрәнү үзәге була, актив әгъзалары арасында М.С.*Рыбушкин* танылa. Казан ун-ты профессоры К.Ф.Фуксның төбәкне өйрәнүгә багышланган хезмәтләре тарихи чыганак буларак бүгенге көнгә кадәр мөһимлеген югалтмый. Аның, ш.у. А.А.*Фукс*, М.К.Казимбәк, И.Н.Березин, А.Ф.Фукс һ.б.ның хезмәтләре Казан төбәге халыкларының тарихи этнографиясен формалаштыруга нигез салалар. Университет каршында сирәк очрый торган әйберләр кабинеты, соңыннан шуның нигезендә этнография музее оештырыла. 1884 тә геогр. һәм этнография каф. ачыла, ул төбәктә этнография фәне үсешенә этәргеч бирә. Шулай ук ун-т каршында минцкабинет (нумизматика музее) оештырылу төбәктә фән буларак Көнчыгыш нумизматикасы формалашуга нигез сала: проф. Х.М.Френ йөзләрчә төрки-татар акчаларын фәнни әйләнешкә кертә. Университет укытучылары башлангычында планлы рәвештә *археологик казу эшләре* үткәрелә. 1837 дә гомуми Т. һәм Россия Т.ы кафедралары оештырыла. Гомуми Т. буенча ун-т программасы шул вакытта ук 3 бүлектән (борынгы заман, урта гасырлар һәм яңа дәвер) тора, шул юнәлешләрнең һәркайсы нәтиҗәле үсеш ала. Әлеге чор укытучылары арасында гомуми Т., Россия Т.ы үсешенә зур өлеш керткән тарихчылар – Н.Я.*Аристов*, С.В.*Ешевский*, П.С.*Кондырев*, Д.А.*Корсаков*, Н.А.*Фирсов*, И.И.*Хәлфин*, А.П.*Щапов*, И.Ф.*Яковкин* һ.б. 1850 елларда проф. С.В.Ешевский ун-тта рус историографиясе буенча беренче лекцияләр курсы укый. Шулай да историография һәм *чыганакларны өйрәнү гыйлемен* Казан ун-тында Д.А.Корсаков исеме б-н бәйлиләр, ул рус историографиясе һәм чыганакларны өйрәнү гыйлеме буенча лекцияләр курсы әзерли һәм шул курсны 1880 нән 30 ел дәвамында алып бара (ул вакытта шуңа охшаш курс Россия ун-тларының берсендә дә укылмый). 1855 тә Көнчыгыш бүлеге Петербург ун-тына күчерелүгә карамастан, төбәктә Көнчыгышны өйрәнү ун-тта гына түгел, *Казан руханилар академиясендә дә* (Н.И.*Ильминский*, М.А.*Машанов*, Н.П.*Остроумов*, Г.С.*Саблуков* һ.б.) дәвам итә. 1863 тә ун-тта Т.-филол. ф-ты (2 бүлектән тора) ачыла, бу Т. фәненең уңышлы үсешен күрсәтә. Бу чорда *тюркология* (И.Н.Березин, М.К.Казимбәк, Ш.*Мәрҗани*, К.*Насыйри*, Х.М.Френ һ.б.) һәм *славяннарны өйрәнү гыйлеме* (О.М.Бодянский, В.И.*Григорович*, Н.В.*Крушевский* һ.б.) барлыкка килә һәм үсә.

19 йөзнең 2 нче яртысында Т. фәне Казан ун-ты каршындагы *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* эшчәнлеге б-н бәйле рәвештә яңа күтәрелеш кичерә. Аның әгъзалары Г.Н.*Әхмәров*, Һ.М.*Атласов*, Н.П.*Загоскин*, А.Ф.*Лихачёв*, Ш.Мәрҗани, П.А.*Пономарёв*, С.М.*Шпилевский*, А.А.*Штукенберг* һ.б. Идел-Кама төбәгендәге борынгы истәлекләрне һәм этнографияне, рус булмаган халыкларның Т.ын һәм көнкүрешен өйрәнәләр. *«Известия Общества археологии, истории и этнографии при императорском Казанском университете»* («Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре») ж-лы (ул Россиянең 136 фәнни оешмасына һәм дөньяның 52 шәһәренә җибәрелә (1894) басылу б-н, җәмгыять эшчәнлеге киң иҗтимагый һәм фәнни яңгыраш ала.

19 йөздә төбәктә ш.у. милли Т. фәне үсеш кичерә. Аңа нигез салучы – Ш.Мәрҗани, татар халкы тарихы буенча күп кенә фундаменталь хезмәтләр авторы. 19 йөз ахырында яңа ысуллы мәдрәсәләрдә һәм мәктәпләрдә беренче булып Россия Т.ы һәм татар халкы Т.ы укытыла башлый (күренекле Т. укытучылары арасында – Й.Х.*Акчура*, Һ.М.*Атласи*, Ә.Ә.*Вәлиди*). Татарлар арасында тарих белемнәрен таратуда мәгърифәтчеләр (к. *Мәгърифәтчелек*) эшчәнлеге һәм *җәдитчелек* идеяләре сизелерлек роль уйный. 20 йөз башында татар Т.ы фәне милли хәрәкәт йогынтысында күтәрелеш чоры кичерә: 1905 тән башлап татар галимнәре актив рәвештә гомуми Т., Рус дәүләте Т.ыннан хезмәтләр язалар, булганнарын тәрҗемә итәләр. Алар төп игътибарны Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы Т.ына юнәлтәләр, бу үз чиратында милли Т. концепциясе формалашуга китерә (Г.Әхмәров, Һ.Атласи, Г.*Баттал*, Ә.Вәлиди, Р.*Фәхретдин* һ.б.).

ТАССР барлыкка килү (1920) төбәк Т.ын өйрәнүгә яңа этәргеч бирә. Иң зур фәнни үзәк дәрәҗәсен элеккечә Казан ун-ты саклый. Ләкин Окт. рев-циясеннән соң Россия Т.ы фәне үсешендә идеологиядәге тамырдан үзгәрешләр б-н бәйле рәвештә принципиаль үзгәрешләр була. Совет хакимиятенең беренче елларында Россиянең барлык югары уку йортларында Т. ф-тлары ябыла, фән буларак, Т. уку программасыннан алына, 1921 дә Казан ун-тының Т.-филол. ф-ты да ябыла. Дәүләт сәясәте элеккеге тарих мәктәбе фәнни традицияләренең тамырын корытуга юнәлтелгән була. Фән буларак Т. үсеше Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте эшчәнлегендә, ш.у. яңа оештырылган фәнни оешмаларда һәм фәнни-тикшеренү учреждениеләрендә дәвам итә. 1920 дә ТАССР Мәгариф халык комис-ты каршында махсус фәнни бүлек төзелә, аның каршында Т.-филол. фәннәре, археол. һәм этнография бүлеге ачыла (җитәкчесе – М.Г.*Худяков*). Бик кыска гына вакыт эшләвенә карамастан, ул фәнни-тикшеренү эшен җайга салып өлгерә; аның нигезендә 1921 дә *Гыйльми үзәк* оештырыла, респ-кадагы фәнни оешмаларның күбесе аның карамагында була. Шәрекъ академиясе каршында 1922 дә Шәрекъне өйрәнү җәмгыяте булдырыла, соңыннан *Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте* итеп үзгәртелә, ул Татарстан һәм татар халкы Т.ын өйрәнү үзәгенә әверелә. Җәмгыять б-н М.Г.Худяков, Н.Н.*Фирсов*, Г.Г.*Ибраһимов*, Г.С.*Губәйдуллин* кебек күренекле галимнәр хезмәттәшлек итәләр. Хакимият дәүләтнең яңа Т. үсешендә, иң беренче чиратта, Коммунистлар партиясе роленең чагылышы б-н кызыксынганлыктан, 1920 дә Окт. рев-циясе һәм РКП(б) Т.ы буенча комиссия төзелә (*Истпарт*); 1920–40 та аның бүлеге ТАССРда да эшли. 1925 тә Г.Ибраһимов җитәкчелегендә *Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросы* оештырыла, аның максаты төбәкне һәм анда яшәүче халыкларны өйрәнү, районнарда та-

рихи-төбәк музейларын оештыру була. 1928 дә *Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте* төзелә, әкренләп Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте һәм Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросы функцияләре аңа күчә. 1920 еллар ахырыннан Т. фәне үсеше процессына актив рәвештә партия-дәүләт органнары катнаша башлый. ТАССРда фәнни оешмалар эшчәнлеген координацияләү өчен 1927 дә *Татар мәдәнияте йорты* ачыла. 1920 елларда тарихи белемнәрне популярлаштыру максатыннан күп кенә фәнни һәм фәнни-популяр басмалар нәшер ителә: «Вестник Научного общества татароведения» («Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте хәбәрчесе»), «Материалы по изучению Татарстана» («Татарстанны өйрәнү буенча материаллар»), «Труды Общества изучения Татарстана» («Татарстанны өйрәнү җәмгыяте хезмәтләре»), «Труды Дома татарской культуры» («Татар мәдәнияте йорты хезмәтләре»), «*Татарстан*» ж-лы һ.б. Әлеге җәмгыять әгъзалары төбәк Т.ын гына түгел, Шәрекъне өйрәнү, татар халкы Т.ы, тюркология үсешенә дә ярдәм итә. Шул вакытта партия-дәүләт органнары фәнни эшчәнлекне контрольдә тотуның яңа формаларын эзлиләр: 1930 да Татар мәдәнияте йорты *Татарстан икътисад фәнни-тикшеренү институты* итеп үзгәртелә, аның максаты респ-кадагы барлык фәнни-тикшеренү эшләрен координацияләү була. Акрынлап фәнни оешмалар ябыла башлый, кайбер фәнни юнәлешләр халыкка каршы дип игълан ителә, күп кенә галимнәр репрессияләргә дучар була (Һ.М.Атласи, Г.С.Гобәйдуллин, Г.Г.Ибраһимов, М.К.*Корбут* һ.б.).

1930 елларда, хәзерге Т. фәне формалашу б-н бәйле рәвештә, белгечләр әзерләүгә зур игътибар бирелә. 1939 да Казан ун-тында бер кафедралы Т. ф-ты (1940–80 дә — тарих-филол.) ачыла. Соңрак түбәндәгеләр аерылып чыга: СССР Т.ы каф., соңыннан шул каф. җирлегендә 20 йөзгә кадәр Ватан Т.ы каф. (Е.А.*Вишленкова*, Г.Н.*Вульфсон*, И.П.*Ермолаев* һ.б.) һәм хәзерге заман ватан Т.ы каф. (Р.К.*Вәлиев*, И.М.*Ионенко*, И.М.*Климов*, А.А.*Литвин*, Ш.Ф.*Мөхәммәдьяров*, И.Р.*Таһиров* һ.б.); гомуми Т. каф., соңрак — борынгы һәм урта гасырлар Т.ы каф. (В.Д.*Жигунин*, Г.П.*Мягков*, А.С.*Шофман* һ.б.), яңа һәм иң яңа Т. каф. (В.И.Адо, Н.А.*Бурмистров*, Р.М.*Вәлиев*, Н.А.Мәҗитова, И.И.*Шәрифҗанов* һ.б.); археология һәм этнология каф. (Е.П.*Бусыгин*, Н.И.Воробьёв, Н.В.*Зорин*, Н.Ф.*Калинин*, Ә.Г.*Мөхәммәдиев*, А.Х.*Халиков* һ.б.); историография һәм чыганакларны өйрәнү гыйлеме каф. (В.В.Астафьев, А.Л.*Литвин*, С.Ю.*Малышева*, А.А.*Сальникова*, Н.М.Силаева һ.б.); Татарстан Т.ы каф. (Р.Ә.*Нәбиев*, Р.Г.*Хәйретдинов* һ.б.); сәяси Т. каф. (С.М.*Михайлова*, Р.И.*Нәфыйгов* һ.б.) оештырыла. 1988 дә татар филологиясе һәм Т.ы ф-тында татар халкы Т.ы каф. ачыла (М.Г.*Госманов*, И.А.*Гыйләҗев*, А.Х.Мәхмүтова, Д.Г.Мостафина һ.б.). Университет тарихчылары төрле юнәлештә эшлиләр, аларның фәнгә керткән өлешләре Россия һәм чит ил галимнәре тарафыннан югары бәяләнә.

1939 дан татар халкы Т.ын өйрәнүнең әйдәп баручы үзәкләреннән берсе *Тел, әдәбият һәм тарих институты* (ТӘТИ) була, аның составында Т., археол., этнография, иҗтимагый фикер (С.Х.Алишев, Р.М.*Әмирханов*, М.И.*Әхмәтҗанов*, Җ.И.*Гыйльманов*, Х.Г.Гыймади, А.М.Җәләлов, Е.П.Казаков, М.К.*Мөхәррәмов*, А.Х.Халиков, Х.Х.*Хәсәнов*, Е.И.*Чернышёв* һ.б.) бүлекләре эшли. Т. бүлеге хезмәткәрләре төбәк Т.ына караган чыганакларны һәм материалларны җыю һәм системага салу буенча зур эш башкаралар, «Татарстан АССР тарихы» (т. 1–2, 1955–60) исемле гомумиләштерелгән хезмәт әзерлиләр һәм бастырып чыгаралар. Алга таба респ-када Татарстан ССР суверенлыгы турында Декларация кабул ителү (1990) Т. фәне үсешендә яңа этап була. Респ-каның яңа статусы 1992 дә *Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе* оештырырга мөмкинлек бирә. Аның эшчәнлегендә әйдәп баручы юнәлешләрнең берсе — гуманитар фәннәр, беренче чиратта, Т. фәне үсеше; шуның нигезендә 1997 дә Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты җирлегендә *Тарих институты* (С.Х.*Алишев*, Р.Г.*Әмирханов*, И.К.Заһидуллин, Д.М.*Исхаков*, Е.П.*Казаков*, Ф.М.*Солтанов*, Р.Г.*Фәхретдинов*, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хәйретдинов, Ф.Ш.*Хуҗин* һ.б.) оештырыла. Институт галимнәре тарафыннан Татарстан һәм татар халкы Т.ы буенча зур фәнни хезмәтләр нәшер ителә: «Татарлар» («Татары», М., 2001); «Иң борынгы заманнардан алып татарлар тарихы» («История татар с древнейших времён», т. 1–7, 2002–15). Татарстан һәм татар халкы турында универсаль белешмә басмалар әзерләү өчен ТР ФА составында *Татар энциклопедиясе институты* (Р.М.*Мөхәммәтшин*, Г.С.*Сабирҗанов*, М.Х.*Хәсәнов*, Р.В.*Шәйдуллин* һ.б.) ачыла. 1990 елларда югары белемне гуманитарлаштыру юнәлеше игълан ителә, шунлыктан респ-каның барлык югары уку йортларында да Т. белеме статусы күтәрелә: Казан пед. ун-тында Т. ф-ты (Н.П.*Муньков*, А.М.*Ременников*, О.В.*Синицын*, Р.Ш.*Таһиров*, Е.И.*Устюжанин* һ.б.), Казан технол. ун-тында дәүләт б-н идарә итү, Т. һәм социол. каф. (У.Б.*Белялов*, О.Н.*Коршунова*, Р.С.*Цейтлин* һ.б.), Казан техник ун-тында Т. каф. (Д.К.*Сабирова*, Я.Ш.*Шәрәпов* һ.б.), Казан финанс-икътисад ин-тында сәяси Т. каф. (В.В.*Иванов*, Э.Р.Таһиров һ.б.), Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында Ватан һәм чит илләр Т.ы каф. (Р.А.*Гарәфетдинов*, Е.Д.*Румянцев*, Р.Р.*Йосыпов* һ.б.), Казан мед. ун-тында Т. һәм социол. каф. (А.М.Җәләлов, Н.Г.Субаев) һ.б. эшли.

*Әд.:* 50 лет поисков и открытий. К., 1989; Жить историей: 60 лет историческому факультету Казанского университета. К., 1999; Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Биобиблиогр. словарь. К., 1999.

*Л.М.Айнетдинова, Р.В.Шәйдуллин.*

**ТАРИ́Х ИНСТИТУТЫ́**, Ш. М ә р җ а н и и с е м., фәнни-тикшеренү ин-ты, ТР Президентының 1996 ел 14 июнь Указы нигезендә Казанда 1997 нең гыйнварында ТР ФАнең Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият, тарих ин-тының тарих, археол. һәм этнография, иҗтимагый фикер тарихы бүлекләре җирлегендә Татарстан һәм татар халкы тарихы өлкәсендәге фәнни тикшеренүләрне стимуллаштыру, югары квалификацияле кадрлар әзерләү өчен оештырыла. 2001 дән Ш.Мәрҗани исемендә. 2014 тән ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагында. Ин-т структурасында (2016) 7 бүлек (татар-болгар цивилизациясе тарихы, яңа тарих, иң яңа тарих, Татарстан Республикасы халыкларының тарихи-мәдәни мирасы, этнологик тикшеренүләр, диннәр һәм иҗтимагый фикер тарихы, мәгълүмати технологияләр), 5 үзәк (Алтын Урда һәм татар ханлыклары буенча тикшеренүләр үзәге, Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге, Керәшен татарлар һәм нагайбәкләр тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү үзәге, Кырым фәнни үзәге, Төньяк-көнбатыш фәнни үзәге) бар. Барлыгы 100 хезмәткәр эшли, шуларның 72се фәнни хезмәткәр, ш.и. 10 фән. д-ры һәм 51 фән. канд. Фәнни-тикшеренү эшләренең өстенлекле юнәлешләре — татар халкы һәм Татарстан халыклары: яңарыш һәм үсеш, ТРда иҗтимагый фикер үсешенең төп тенденцияләре. Төп фәнни юнәлешләр: борынгы заманнардан алып татар халкы тарихы; татар иҗтимагый һәм фәлсәфи фикере үсешенең төп юнәлешләре; татар халкы тарихында һәм мәдәниятендә ислам дине; татар халкының этносәяси тарихы; ТРда хәзерге сәяси, этномәдәни, этносоциаль процесслар; татар халкының традицион матди һәм рухи мәдәнияте формалашу һәм үсеше; татар педагогикасы тарихы. Ин-т ТР һәм РФнең акад. учреждениеләре һәм югары уку йортлары, музейлары, архивлары, китапханәләре б-н тыгыз иҗади бәйләнештә. Якын һәм ерак чит ил галимнәре б-н фәнни багланышлар ныгый һәм киңәя. Ин-т «Золотоордынское обозрение», «Крымское историческое обозрение», «Кряшенское историческое обозрение» ж-ларын, «Золотоордынская цивилизация», «Нумизматика Золотой Орды», «Из истории и культуры народов Среднего Поволжья», «Средневековые тюрко-татарские государства» еллык җыентыкларын нәшер итә. Иң әһәмиятле басмалар: «Татарлар» («Татары», М., 2001; ТРның Дәүләт бүләге, 2003) коллектив монографиясе; «Иң борынгы заманнардан алып татарлар тарихы» («История татар с древнейших времён», т. 1–7, 2002–15) «Tartarica» (К.–М.–СПб., 2006), «Tartarica. Этнография» (К.–М., 2008), «Bulgarica. Болгар цивилизациясе чоры һәм пространствосы: Атлас» («Bulgarica. Время и пространство Болгарской цивилизации: Атлас», К.–М., 2012) атласлары. Фәнни тикшеренүләр үсешенә саллы өлеш кертүчеләр — Я.Г.Абдуллин, С.Х.Алишев, Р.Г.Әмирханов, А.Ш.Әсәдуллин, Д.М.Исхаков, Е.П.Казаков, Р.М.Мөхәммәтшин, А.Г.Петренко, Р.Г.Фәхретдинов, Ф.Ш.Хуҗин. Ин-т директоры — Р.С.*Хәкимов* (1997 дән).

**ТАРИ́Х ФӘНЕ́Н ӨЙРӘНҮ́ ГЫЙЛЕМЕ́ (ИСТОРИОГРА́ФИЯ)**, к. *Татарстан һәм татар халкын өйрәнү гыйлеме.*

**ТАРИХИ́ ҖЫРЛА́Р**, фольклор жанры, тарихи вакыйгалар турында эпик җырлар; көйләп һәм көйсез башкарылалар. Т.җ. эчтәлеге б-н сугышларга, социаль һәм милли изүгә,

аерым катлау кешеләренең тормыш-көнкүреш хәлләренә бәйле. Татар фольклорында Т.җ. Болгар дәверендә үк барлыкка килә. Аларда башка илләр б-н сәүдә элемтәләре («Болгарданмы киләсез?», «Шәһре Кашан», «Шәһре Болгар»); Урта Азия, Кавказ яисә башка илләргә коллыкка сатылган Болгар кызлары язмышы («Болгар иленең кызлары», «Болгар ятимәләре») турында бәян ителә. *Сөембикәгә* багышланган Т.җ. Казан ханлыгы чоры б-н бәйле. 18–19 йөзләр — жанрның чәчәк аткан чоры. «Пугачау патшаны күрсә идең», «Салават Юлай» Т.җ.ы крәстиян кузгалышларын тасвирлауга багышлана. Качкыннар турында мишәрләрдән язып алынган «Ташкай», «*Качкын Хәмидулла*», «Качкынның михнәте бигрәк зур» җырлары качкын солдатларга, каторжаннарга багышлана. Охшаш тематикалы тарихи җырлар 20 йөз башында да барлыкка килә. Күпчелек җырларда халык иҗаты өчен гадәти табигать образлары — кара урман, агымсулар, йолдызлы күк йөзе һ.б. 1905–07 елгы рев-ция һәм 1917 елгы Окт. рев-циясе дәверендә якынлашып килгән социаль үзгәрешләр, якты яңа тормыш турындагы җырлар киң таныла. Нигездә, алар — татар теленә тәрҗемә ителгән «Интернационал», «Марсельеза», «Варшавянка», «Смело, товарищи, в ногу» («Кыю атлагыз, иптәшләр») һ.б. революцион җырлар. Татар һәм рус телләрендәге Т.җ.ның тулырак җыелмасы Н.Ф.Катановның «Казан татарларының тарихи җырлары» («Исторические песни Казанских татар», 1899) китабында китерелгән. Аерым Т.җ.ның текстлары 1960–70 елларда чыккан фольклор җыентыкларына кертелә.

*Әд.:* Урманчеев Ф. Тарихи җырлар // Казан утлары. 1969. № 3; Яхин А.Г., Бакиров М.Х. Фольклор жанрларын тикшерү тәҗрибәсе. К., 1979; Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. К., 1988.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ТАРИХИ́ МӘЧЕ́Т**, Мәскәүдәге беренче мәчетләрнең берсе; архит-ра истәлеге. Зур Татар урамында урнашкан. Мәчет төзү өчен җир кишәрлеге Мәскәү татарларына Россия хөкүмәте тарафыннан 1812 елгы Ватан сугышында татар полклары күрсәткән батырлыкларга рәхмәт билгесе буларак бүләк ителгән. 1816 да төзелә. 19 йөзнең 2 нче яртысында реконструкцияләнә. Мәчетнең гөмбәз б-н төгәлләнгән зал өлеше стильләшкән конструктив һәм көнчыгыш-мөселман архит-расының декор. элементлары б-н бизәлгән. Тупыпочмаклы михраб сигезкырлы барабандагы тәбәнәк гөмбәз б-н очланган. Төп фасад диварындагы калын вертикаль терәкләр һәм чөйсыман капительләр, манара нигезендәге өч терәкле кечкенә а́ркалар һәм кәрниз астындагы дивар чыгынтылары бинага шәрекъ колориты биреп торалар. 1937 дә Т.м.тә гыйбадәтләр туктатыла. 1967 дә мәчетнең һәм манараның очлары җимертелә. 1993 тә мәчет кабат мөселманнарга кайтарыла.



Мәскәүдәге тарихи мәчет. 19 йөзнең 2 нче яртысы.

**ТАРИХИ́ СҮЗЛӘ́Р**, искергән, кулланылыштан төшеп калган, юкка чыккан төшенчәләрне белдерүче сүзләр яки тотрыклы сүзтезмәләр. Архаизмнардан аермалы буларак, синонимнары юк. Дәреслекләрдә һәм фәнни әдәбиятта — терминологик мәгънәдә, матур әдәбиятта тарихи колорит тудыру өчен кулланылалар. Т.с.не генетик һәм семантик билгеләренә карап төркемлиләр. Генетик билгеләре ягыннан татар лексикологиясендә борынгы төрки, иске төрки, рев-циягә кадәрге һәм рев-циядән соңгы Т.с.не аерып өйрәнәләр. Күпчелек борынгы төрки Т.с. татар лексикасыннан озак вакытка юкка чыгып тора. Алар, төрки рун язуын һәм борынгы төрки чорны өйрәнү б-н бәйле рәвештә, башта тарихи-филол. тикшеренүләрдә, соңрак матур әдәбиятта яңадан күренә башлыйлар: тәңре — Аллаһ, күк; каган — ил б-н идарә итүче; балбал — таш сын һ.б. Иске төрки Т.с.нең күпчелеген гарәп-фарсы алынмалары тәшкил итә: ахун — өлкән мулла; мөэмин — дингә ышанучы, диндар, хак мөселман; гарасат — соңгы хөкем чыгарылачак мәйдан, кыр. Иске төрки Т.с. арасында төп төрки сүзләр дә бар: абыстай — мөселман дини мәктәбендә укытучы; би — кенәз; кәнизәк — асрау, хезмәтче, кол хатын-кыз. Рев-циягә кадәрге Т.с.нең күпчелеген рус теленнән кергән сүзләр яисә рус сүзләре һәм сүзтезмәләренең калькалары тәшкил итә: баяр (бояр), урәтник, кенәз, народник, жандарм. Рев-циядән соңгы Т.с.гә рев-ция һәм совет чоры төшенчәләрен белдерүче сүзләр һәм сүзтезмәләр керә: ак гвардия, батраклар комитеты, нэпман. Семантик билгеләре ягыннан Т.с. түбәндәге төркемнәргә бүленә: а) иҗтимагый-сәяси: ямщик, коммуна, меньшевик, эсер, продразвёрстка; б) адм.: волость, кулак, кантон; в) көнкүреш: тубал, чабата, киле; г) йола: калым, бирнә, талак; д) дини: гыйбадәт, намаз, мулла, мөфти һ.б. Татар телендә Т.с.не өйрәнү һәм аларны классификацияләү б-н Ш.Г.Рамазанов, В.Х.Хаков, Г.Х.Әхәтов, М.З.Зәкиев, Ә.М.Ахунҗанов, Х.Р.Курбатов, К.С.Сабиров һ.б. галимнәр шөгыльләнә.

*Әд.:* Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле: Лексикология. К., 1999; Зинина А.С. Историзмы и их разновидности в татарской лексике // Двуязычие: Типология и функционирование. К., 1990.

**ТАРКО́ВСКИЙ** Арсений Александрович (12.6.1907, Херсон губ. Елизаветград ш. — 27.5.1989, Мәскәү), шагыйрь, тәрҗемәче. «Кар алдыннан» («Перед снегом», М., 1962), «Җиргә — җирнеке» («Земле — земное», М., 1966), «Хәбәрче» («Вестник», М., 1969), «Шигырьләр» («Стихотворения», М., 1974), «Тылсымлы таулар» («Волшебные горы», М.,1978), «Кышкы көн» («Зимний день», М., 1980), «Яшьлектән картлыкка кадәр» («От юности до старости», М., 1987) шигъри җыентыклары авторы. Т. лирикасына кешенең рухи тормышының бербөтенлеген раслау, кырыс классик стильгә тартылу хас. 1941 елның октябреннән декабренә кадәр Чистайда эвакуациядә була. 1942 нең башында үзе теләп фронтка «Хәрби тревога» («Боевая тревога») армия газетасының хәбәрчесе булып китә; Мәскәү янындагы, Көнбатыш, Брянск, 2 нче Белоруссия һәм 1 нче Балтыйк буе фронтлары сугышларында катнаша. Яраланып, аякларын кистергәннән соң, демобилизацияләнә. Чистай мотивлары «Бир кулыма Никола иконасын...» («Вложи мне в руку Николин образок...»), «Качак» («Беженец»), «Агачтан озын алтарьлар төзим...» («Дровяные, погонные возвожу алтари...»), «Үлем бар нәрсәгә салкын кулын суза...» («Смерть на всё накладывает лапу...»), «Эндәшәм — ишетми, каты йоклый Марина...» («Зову — не отзывается, крепко спит Марина...»), «Озату» («Проводы»), «Кер юу» («Стирка белья»), «Львов тегүчесе» («Портной из Львова») шигырьләрендә чагылыш таба. Гарәп, әзәрбайҗан, грузин, чечен, төрекмән, серб, поляк һ.б. телләрдән тәрҗемәләр эшли. Рус теленә Г.Тукай, М.Җәлил шигырьләрен тәрҗемә итә. СССР Дәүләт бүләгенә ия була (1989, үлгәннән соң). Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар Дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр: Избранное. М., 2000.

*Әд.:* Волкова П.Д. Арсений Тарковский: Жизнь семьи и история рода. М., 2002.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ТАРЛА́У** (Elymus), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 50 төре билгеле, Европа, Азия һәм Американың уртача поясларында таралганнар. ТР терр-ясендә 2 төре бар. Озын Т. (E. giganteus) читтән кертелгән үсемлек, комсу туфракларда, тимер юлларда очрый. Кугасыман Т. (E. junceus) көньяк-көнчыгыш районнарда далаланган тау битләрендә үсә. 130 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы озын. Сабагы калын, башак асты төкчәле. Яфраклары күгелҗем-яшел, каты. Башаклары куе, ике рәтле. Май–августта чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Тозлы туфракка, корылыкка чыдам. Терлек азыгы, декоратив үсемлек. Комнарны ныгыта. Кугасыман Т. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ТАРЛА́У** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 18 *км* көнчыгыштарак, Кама елгасының уң ярында урнашкан. 2010 елда 461 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 65%, татарлар — 32%) яши. Урта мәктәп. Покров чиркәве (2001 дән). 20 йөз башында сәүдәгәр Д.А.Стахеев үзенең гаиләсе өчен ял урыны буларак нигез сала. 1920 еллар башында Стахеев дачасы җирлегендә Бондюг химия з-ды эшчеләре өчен ял йорты төзелә (1928 дә «Тарловка» кымыз б-н туберкулёздан дәвалау санаторие итеп үзгәртелә). 1941–45 тә 4089 нчы номерлы эвакуация госпитале урнаша, анда 10 меңгә якын

Совет армиясе сугышчысы дәвалана. Рәсми чыганакларда санаторий каршындагы торак пункт Тарловка санаторие яки Тарловка санаторие посёлогы дип аталган. Башта ТАССРның Чаллы кантонына керә, 1930 ның 10 августыннан — Чаллы р-нында, 1959 ның 31 июленнән Чаллы шәһәре карамагында, 2009 да Алабуга р-нына бирелә, 2010 ның 9 июнендә авыл статусын ала һәм хәзерге исемен йөртә башлый. Т. тирәсендәге матур урыннар курорт зонасы булып исәпләнә. Монда рәссамнар И.И.*Шишкин*, К.А.*Васильев* иҗат итәләр. Т. янында «КАМАЗ-Мастер» командасы полигоны урнашкан.

**ТАРЛА́У** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 28 *км* көнбатыштарак, Балтач-Кукмара автомобиль юлы буенда. 2010 елда 148 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. Мәчет. 1678 дән Пустошь Тарловка исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Тарлова, Торлова буларак мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 620,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Ядегәр волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дән — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 133 ир-ат; 1859 да — 205, 1897 дә — 303, 1908 дә — 325, 1920 дә — 343, 1926 да — 361, 1938 дә — 351, 1949 да — 312, 1958 дә — 172, 1970 тә — 139, 1979 да — 148, 1989 да — 151, 2002 дә — 153 кеше.

**ТАРЛА́У** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 12 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 75 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1930 елларда нигез салына. Оешкан көненнән Ютазы р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1938 дә — 189, 1949 да — 152, 1958 дә — 132, 1970 тә — 168, 1979 да — 135, 1989 да — 107, 2002 дә — 86 кеше.

**ТАРЛА́Ш** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 27 *км* көньяктарак, Архиерей күле янында урнашкан. 2010 елда 59 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Покровский исеме б-н билгеле. Халкы башта Казан архиерей йортына карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, он тарту һәм тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Покров чиркәве (1801–06 да төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1868 дә ачыла), 5 җил тегермәне, 2 тимерчелек, 8 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3722,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Столбище волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенск, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 196 ир-ат; 1859 да — 894, 1897 дә — 1495, 1908 дә — 1719, 1920 дә — 1908, 1926 да — 2398, 1949 да — 894, 1958 дә — 665, 1970 тә — 414, 1979 да — 248, 1989 да — 136, 2002 дә — 86 кеше.

**ТАРЛА́Ш КҮЛЕ́**, к. *Архиерей күле.*

**ТАРМАКМЫЕКЛЫ́ КЫСЛАСЫМАННА́Р** (Cladocera), яфрагаяклылар отрядыннан кысласыманнар асотряды. Барлыгы 400 гә якын, Татарстан терр-ясендә якынча 60 төре билгеле. Аеруча киң таралган төрләре босмина (Bosmina), дафния (Daphnia) һәм хидорусларга (Chydorus) карый. 4–7 пар аяклы вак (озынлыгы 0,2–10 *мм*) планктон яки бентос кыслачыклары, башлары томшыксыман үсентеле һәм еш кына ике яклы үтә күренмәле хитинлы кабык б-н капланган. Суда һәм су төбендә ике яки бертармаклы антенналарын кискен селтәп хәрәкәтләнәләр. Йөзмә детрит һәм вак суүсемнәрне фильтрацияләп тукланалар. Җаен уңай шартлар булганда сулыкларда партеногенетик ысул б-н үрчүче ана затлар гына очрарга мөмкин. Көзгә таба яисә тереклек шартлары начарлана башлагач, популяциядә ата затлар күренә башлый. Аталанганнан соң, гадәттә, кышкы яки хәрәкәтсез яткан күкәйләр җитлегә. Язын алардан яшь кыслачыклар чыга. Аквариум тотучылар һәм балык үрчетүчеләр еш кына Т.к.ны ясалма азык буларак үрчетәләр.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1968. Т. 2; Определитель пресноводных беспозвоночных Европейской части СССР. Л., 1977.

*В.А.Яковлев, Т.А.Кондратьева.*


**ТАРН-ВАР** посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 5 *км* төньяктарак урнашкан. 1927 елда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Иске Чаллы волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында, 2001 нең 27 июненнән Нурлат шәһәре составында. Халык саны: 1938 дә — 136, 1949 да — 101, 1958 дә — 105, 1970 тә — 1406, 1979 да — 97, 1989 да — 73 кеше.

**ТАРПИ́ЩЕВ** Хөсәен Гани улы (1894, Пенза губ. Йөнә а. — 14.8.1937), сәясәт эшлеклесе. 1917 елда Мәскәү коммерция ин-тында укый. 1918 нең башыннан Кәттә-Курган шәһәрендә (хәзер Үзбәкстан Респ-касы), совет хакимиятен урнаштыру өчен көрәшкә кушыла, Эшче һәм крәстиян депутатларының өяз советы әгъзасы. 1918 нең ноябреннән Кызыл Армиядә. Көнчыгыш фронтның 1 нче армиясе сәяси бүлегенең мөселман секциясе мөдире; Беренче аерым Идел буе татар укчылар бригадасында сәяси эш алып бара; 2 нче Төркестан дивизиясенең Сәяси бүлек башлыгы; Идел аръягы хәрби округының Сәяси идарәсе хезмәткәре (Самара ш.); Революцион Хәрби Советның Сәяси идарәсендә Көнчыгыш бүлеге мөдире. 1920 еллар башында Төрки халыклар үзәк бюросы әгъзасы, РКП(б) ҮК каршындагы татар-башкорт секциясе бюросы әгъзасы һәм инструкторы, РКП(б)ның Донецк губкомы каршындагы милли азчылык бүлеге мөдире. 1925 тән Казанда эшли: СССР Дәүләт банкының Казан бүлеге идарәчесе урынбасары (1925–30), ТАССРның финанс халык комиссары (1930). Соңыннан Урал-Казакъстан сәнәгать академиясендә (Свердловск ш.) укый. 1932 дә «Крәстиян иттифагы» милләтчеләр фетнәчел оешмасы»нда катнашкан өчен кулга алына, 1933 тә 3 елга Архангельск шәһәренә сөргенгә җибәрелә, 1935 тә ирекkә чыгарыла; 1937 дә кабат кулга алына, 1937 нең 14 августында үлемгә хөкем ителә; атып үтерелә. 1957 дә аклана.

*Әд.:* Х а й р у т д и н о в Р.Г. Тарпищев Хусаин Ганеевич // Возвращённые имена: Док. очерки. К., 1990; Книга Памяти жертв политических репрессий. К., 2005. Т. 14.

*Р.Г.Хәйретдинов.*

**ТАРПИ́ЩЕВ** Шамил Әнвәр улы (7.3.1948, Мәскәү), спортчы, тренер (теннис), РФнең спорт эшлеклесе, СССРның спорт остасы (1966), РСФСР, СССРның атказ. тренеры (1981, 1985). Дәүләт үзәк физкультура ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1970). Спорт б-н 1956 елда шөгыльләнә башлый; беренче тренеры — И.Всеволодов. 1962–70 тә — «Труд» ирекле спорт җәмгыяте, 1971–74 тә армия үзәк спорт клубы өчен чыгыш ясый; 1970–73 тә СССРның иң яхшы теннисчылар унлыгына керә. Сочидагы (1968, ялгыз һәм катнаш, 1967 — парлы разрядта), ГДРдагы (1970, ялгыз һәм парлы разрядларда) халыкара турнирларда; Мәскәүнең көчле теннисчылары (1968), СССР (1972–73); Зигмунд мемориалы (1976, ялгыз, 1969–70 — парлы разрядта) турнирларында; теннисчы-тимерюлчылар арасында дөнья чемпионатында (1970, ялгыз һәм парлы разрядларда) җиңүче. 1974–91 дә Мәскәү шәһәр советының «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тренерлык эшендә, бер үк вакытта СССР, БДБ җыелма командаларында өлкән тренер (1992), РФнең Физкультура һәм туризм буенча дәүләт ком-ты рәисе (1994–96), 1997 дән Россия җыелма командасында өлкән тренер. Бер үк вакытта Дэвис кубогына (1974–92 һәм 1997 дән), Кремль кубогына (1974–94 һәм 2000 нән) турнирларда СССР, Россия милли командаларында капитан, Азия-Европа матчында Европа җыелма командасы капитаны (1983), СССР (1991), БДБ (1992 дән) Теннис федерациясе рәисе, Бөтенроссия теннис ассоциациясе президенты (1999 дан; 2002 дән — Россия Теннис федерациясе), РФ Президенты Б.Н.Ельцинның физкультура һәм спорт буенча киңәшчесе (1992–94), РФ Президенты каршындагы Физкультура һәм спорт буенча координацион ком-т рәисе (1993–97), «Кремль кубогы» директорлар советы рәисе һәм Мәскәү мэрының спорт буенча киңәшчесе (1996 дан); Россия Олимпия ком-тының башкарма ком-ты (1994 тән), Халыкара олимпия ком-ты (1996 дан), РФ Президенты каршындагы Физкультура һәм спорт советы президиумы (2002 дән), «Спорт иле Россия» бөтенроссия


Ш.Ә.Тарпищев.

ирекле спорт җәмгыятенең югары советы (2005 тән), «Теннис+» ж-лы редакция коллегиясе әгъзасы. «Слава-2002» («Иң яхшы тренер» номинациясендә) һәм «Серебряная лань» (2003, Россиянең Спорт журналистлары федерациясе) милли премиясе, Мордва Респ-касы Дәүләт бүләге (2003) лауреаты. Казанда Теннис академиясе төзелеше инициаторы. «Почёт билгесе», 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Самый долгий матч. М., 1999; Школа тенниса. М., 2001 (автордаш); Академия тенниса. М., 2002 (автордаш); Матч продолжается. М., 2006; Первый сет = The First set. М., 2008.

**ТАРТА́Р**, т а р т а й (Crex crex), көтүче кошлар семьялыгындагы кош. Евразиядә таралган. ТР терр-ясендә барлык районнарда да очрый, 1920 еллар б-н чагыштырганда аның саны шактый кимеде һәм 10–15 мең зат (1996) тәшкил итә. Болыннарда, сазлыкларда, а.х. чәчүлекләрендә яши. Гәүдәсе якынча 30 *см* озынлыкта, ян-ягы кысылган, авырлыгы 150–200 *г*. Каурыйлары коңгырт-җирән, аркасы аксыл, ян-яклары, язын һәм җәен бүксәсе һәм түше кызгылт-соры, күзен кызгылт-җирән төстә. Канатлары саргылт ак тимгелле. Томшыгы нык, кыска. Тиз йөгерә, начар һәм сүлпән оча. Төнлә актив. Майда очып килә. Оясын куак астындагы коры үлән түшәлгән чокырчыкта кора. Кызгылт-көрән тимгелле 7–12 аксыл йомырка сала. Балалары июль башында чыга. Бөҗәкләр, моллюсклар, суалчаннар, үсемлек орлыклары б-н туклана. Спорт сунарчылыгы объекты. Сентябрьдә берәрләп яки зур булмаган төркем булып очып китәләр.

**ТАРТЫ́К АВАЗЛА́Р**, үзенчәлекләре ягыннан сузыкларга (к. *Вокализм*) капма-каршы булган сөйләм авазлары төркеме. Акустик яктан Т.а.ның гомуми куәте сузык авазларныкына караганда чагыштырмача кимрәк, һәм алар төгәл форманта төзелешенә ия булмаска мөмкин. Артикуляция (әйтелеш) ягыннан Т.а. сөйләм органнарының бугаз өсте куышлыкларында шау ясаучы киртә барлыкка килүе б-н аерылып торалар; тартыкларны әйткәндә, киеренкелек сөйләм аппаратының бер өлешендә генә була, һәм киртә дә шул урында ясала. Т.а. артикуляциясе вакытында шау ясаучы сөйләм органы гына түгел, тон ясаучы орган — бугаз да катнаша: тавыш ярылары тибрәнгәндә, тон барлыкка килә.

Хәзерге татар теленең авазлар системасы 26 төп һәм алынма сүзләрдә кулланыла торган 5 — [ц], [щ], [в], [ᵀч], [х'] фонемаларыннан гыйбарәт. Аваз ясалганда тавыш ярыларының катнашуыннан чыгып, Т.а. саңгырау: [п], [т], [с], [х], [ш], [ч], [қ], [к], [ф], [х], [һ], [ц], [щ], [ᵀч], ['] — «һәмзә» һәм яңгырау: [б], [в], [w], [ж], [җ], [г], [ғ], [р], [м], [н], [ң], [л], [й], [д], [з] — тартыкларга бүлеп караладар. Шау ясаучы киртәнең характерыннан чыгып, Т.а. йомык, ярымйомык һәм йомык-үтешле төрләргә бүленәләр. Йомык тартыклар ясалганда, ике актив сөйләм органы — аскы һәм өске иреннәр яки актив орган б-н пассив орган, мәс., тел б-н аңкау бер-берсенә якын килеп йомылалар. Һава агымы ул йомыклыкны я әйләнеп үтәргә, яисә шартлап чыгып китәргә тиеш була. Беренче очракта — шартлаулы [п], [б], [т], [д], [к], [қ], [г], ['] Т.а.ы, икенчесендә [ᵀч], [ц] аффрикатлары ясала. Актив орган икенче актив яисә пассив орган б-н якынаерга мөмкин, һава агымы алар арасында барлыкка килгән ярыктан ышкылып чыгып китә. Андый артикуляция ярымйомык Т.а. ясалуга китерә. Алар арасында бер фокуслы Т.а. ([ф], [в], [с], [ғ], [з], [х], [һ], [w], [х']) аерып карала. Аларны әйткәндә, шау бер урында гына хасил була (аларга ш.у. шактый озын ярыклы бер сузылмалы фокуслы [ж], [ч], [й] һәм ике фокуслы [ш], [щ], [җ] Т.а.ын кертеп карыйлар).

Шау хасил итүче киртәнең кайсы актив орган тарафыннан ясалуына карап, Т.а. ирен, тел, увуляр (кече тел), фарингаль (йоткылык), ларингаль (бугаз) тартыкларга бүленәләр. Ирен тартыклары иреннәр кысылу (ирен-ирен тартыклары: [б], [п], [w], [м]), аскы ирен б-н өске тешләрнең бер-берсенә тиюе (ирен-теш тартыклары: [в], [ф]) нәтиҗәсендә ясалалар. Тел тартыклары, телнең алгы, урта яки арткы өлешенең хәрәкәтеннән чыгып, тел алды ([д], [т], [з], [с], [н], [л], [ж], [җ], [ч], [ᵀч], [ш], [р], [ц], [щ]), тел уртасы ([й]) һәм тел арты ([к], [г], [х], [ң]) тартыкларына бүленәләр. Увуляр тартыклар кече телнең (увула) йомшак аңкауга хәрәкәте нәтиҗәсендә барлыкка киләләр; бу очракта тел төбе пассив орган булып тора ([қ], [ғ], [х], [ң]). Йоткылык стеналарының бер-берсенә якын килеп кысылуы нәтиҗәсендә фарингаль тартык ([һ]) барлыкка килә. Тавыш ярыларының кысылуы яки бер-берсенә якын килүе нәтиҗәсендә ларингаль тартык (['']) ясала.

*Әд.:* Татар грамматикасы. М.–К., 1998. 1 т.; С а ф и у л л и н а Ф.С., Х ә к и м җ а н Ф.С. Татар әдәби теле: Фонетика. К., 2001; С а ф и у л л и н а Ф.С., З ә к и е в М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2002; С а л и м о в Х.Х. Просодическая система татарского языка. Елабуга, 2003.

*А.М.Сәгыйтова.*

**ТАРТЫЛУ́** (гравитация, гравитацион тәэсир итешү), физик материянең теләсә кайсы төрләре арасындагы универсаль тәэсир итешү (гадәти матдәләр, физик кырлар). Әгәр бу тәэсир итешүләр чагыштырмача көчсез булса һәм җисемнәр яктылыкның вакуумдагы тизлегенә (*с*) карата акрынрак хәрәкәт итсәләр, Ньютонның бөтендөнья тартылу законы кулланыла. Тәэсир итешүләр көчлерәк булган очракта (с б-н чагыштырырлык тизлекләр һәм көчле кырлар), А.Эйнштейнның гомуми чагыштырмалылык теориясе (ГЧТ, 1905) кулланыла, ГЧТ Ньютонның тартылу теориясен махсус чагыштырмалылык теориясе нигезендә гомумиләштерә, аның нигезендә исәп системасы тизләнешле хәрәкәт иткәндә туган инерция көчләре б-н тартылу көчләренең локаль аерылгысызлыгы — эквивалентлыгы принцибы ята. Бу принцип бирелгән Т. кырында, бер үк башлангыч шартлар булганда, теләсә нинди массалы һәм физик табигатьле җисемнәрнең бер үк төрле хәрәкәт итүендә чагыла. Эйнштейн теориясе Т.ны физик материянең фәза-вакытның геом. үзлекләренә тәэсире дип сурәтли; үз чиратында, әлеге үзлекләр материя хәрәкәтенә һ.б. физик процессларга тәэсир итәләр. Җисемнәрнең шундый фәза-вакыт кәкресендә «инерция буенча» хәрәкәте (ягъни гравитация көчләреннән башка тышкы көчләр юк) геодезик (кәкре) сызыклар буенча (кәкрәймәгән фәзадагы турыларга охшаш) бара. Көчле Т. кырында гадәти өч үлчәнешле фәза геометриясе нәевклид геометриягә әйләнә (Евклид геометриясеннән бишенче постулатның үтәлмәве б-н аерыла; к. *Лобачевский геометриясе*), ә вакыт кырның тышындагы вакыттан акрынрак уза. Эйнштейн теориясе Т. кыры үзгәрүнең яктылыкның вакуумдагы тизлегенә тигез булган соңгы тизлеген, кара тишекләр барлыкка килү мөмкинлеген һ.б.ны фаразлый.

Казанда чагыштырмалылык һәм гравитация теориясе (ЧГТ) буенча фәнни юнәлеш барлыкка килү нәевклид геометриясенә нигез салучы Н.И.Лобачевский исеме б-н бәйле. 1930 елларда Казан ун-тында ЧГТ кафедрасына нигез салучы һәм аның беренче мөдире А.З.*Петров* 3 типтагы фәзаларны исәпли башлый, 1954 елда 3 типтагы Т. кыры ачыла, 1957 дә Эйнштейн тигезләмәләренең Т. кырларын сурәтләүче яңа төгәл чишелеш классларын инвариант-төркемләп анализлау эшләнә (Эйнштейн фәзаларының өч төре турындагы Петров теоремалары дөнья әдәбиятында «Петров типлары» дигән исем ала). Инглиз физиклары Ф.Пирани, Г.Бонди һ.б. фәзаның икенче яки өченче тип Т. кырына керүе гравитацион нурланыш булуын күрсәтә дигән нәтиҗә ясыйлар. Петров һәм аның шәкертләре Т. кырларын изометрик (А.З.Петров, В.Р.Кайгородов), геодезик (В.И.Голиков), конформ (Р.Ф.Билалов), проектив һәм афин (А.В.Әминова) рәвешүзгәртүләр формасындагы симметрия төркемнәре буенча классификациялиләр. Әлеге хезмәтләр ЧГТ-дә Эйнштейн тигезләмәләренең төгәл чишелешләрен эзләү программасының нигезен тәшкил итәләр һәм яңа — үзара тәэсирләрне күчерә торган материаль системаларның, гравитацион, электромагнит һ.б. физик кырларның физик үзлекләре геом. яки физик табигатьле төрле объектларның автоморфизмнары төркемнәре буларак билгеләнә торган тикшеренүләрне башлап җибәрәләр. 1962 дә Петров Казан ун-тының ЧГТ кафедрасы каршында экспериментал лаб-я оештыра, лаб-янең төп фәнни-тикшеренү юнәлешләре матем. физиканың геом. алымнарын эшләү, инвариант-төркемләү алымнарын физик кырларның нәсызыкча тигезләмәләрен тикшерүдә, ш.у. космология һәм релятивистик астрология мәсьәләләрен чишүдә куллану б-н бәйләнгән. 1980 елларда В.Р.Кайгородов, З.Г.Морзаханов һәм А.Б.Балакин тырышлыгы б-н Казан ун-тының ЧГТ каршындагы гравитацион-дулкын астрономиясе лаб-ясендә гравитация нурланышын детекторлау һәм

Эйнштейн теориясен нигезләүгә караган тәҗрибә эшләре башлана. 1991 дә ТР хөкүмәте периодик гравитация нурланышын детекторлау проектын раслый, һәм 1994 тә «Дулкын» Гравитацион-дулкын тикшеренүләре фәнни үзәге төзелә (ТР ФА ин-ты хокукларында). 2016 ның 11 февралендә халыкара LIGO һәм VIRGO берләшмәләре тарафыннан гравитация дулкыннарын беренче тапкыр турыдан-туры детекторлау турында хәбәр ителә. Ш.у.к. *Казан геометрия фәнни мәктәбе*.

*Әд.:* Ф о к В.А. Теория пространства, времени, тяготения. М., 1961; П е т р о в А.З. Пространство Эйнштейна. М., 1961; ш у л у к. Новые методы в общей теории относительности. М., 1966; А м и н о в а А.В. Проективные преобразования псевдоримановых многообразий. М., 2003.

*А.В.Әминова.*

**ТАРТЫ́М**, *исем* сүз төркеменең грамматик категориясе, төрки телләргә генә хас, предметның нинди дә булса затка (яки икенче бер предметка) караганлыгын белдерә. Татар телендә Т.ның өч зат, берлек һәм күплек сан формалары була. Предметның 1 нче һәм 2 нче затка караганлыгы түбәндәгечә белдерелә: 1) Т. кушымчалары ярдәмендә генә: илем, илең, илебез, илегез; 2) иялек килешендәге зат алмашлыгы һәм тартымсыз исем сүзтезмәсе ярдәмендә: **минем** ил, **синең** ил, **безнең** ил, **сезнең** ил; 3) иялек килешендәге зат алмашлыгы һәм тартым кушымчалы исем б-н: **минем** илем, **синең** илең, **безнең** илебез, **сезнең** илегез. Предметның 3 нче затка (яки затларга) караганлыгы, гадәттә, иялек килешендәге 3 нче зат алмашлыгы һәм тартым кушымчалы исем б-н белдерелә: **аның** иле, **аларның** илләре; 3 нче зат тартымлы исем б-н генә дә белдерелә ала: бала**сы**, китаб**ы**, ил**е**.

*Әд.:* Татар грамматикасы. Морфология. М.–К., 2002. 2 т.; Х и с а м о в а Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006; И в а н о в С.Н. К истолкованию категории принадлежности // Советская тюркология. 1973. № 4.

**«ТАРТЫ́Ш»**, иҗтимагый-сәяси газета. Әстерхан коммунист-мөселманнар оешмасы һәм РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты каршындагы Әстерхан губернасының мөселман эшләре буенча комис-ты органы. 1917–19 елларда Әстерхан шәһәрендә татар телендә атнага 2 тапкыр нәшер ителә, барысы 64 саны чыга. 1917–18 дә «Солдат ялкыны» исеме белән дөнья күрә. Мөхәрририяткә Д.Биньядзадә, К.Гобәйдуллин һ.б. керә. Актив авторлары арасында — Ә.Гомәров, В.Салихҗанов, Х.Сәйфи, Г.Бәхтиев, Ш.Таҗетдинов, К.Габидуллин. Совет хакимиятенең декретлары, боерыклары һәм күрсәтмәләре, В.И.Ленин мәкаләләре, Россия мөселман-большевиклар съездларының карарлары, ВКП(б) программалары, чит ил, гомумроссия һәм төбәк яңалыклары басыла. «Революция дулкынында», «Кызыл фронтта» һ.б. сәхифәләрдә Кызыл Армиягә, соц. төзелешкә, Татар-башкорт комис-ты эшчәнлегенә багышланган язмалар, фронт хәбәрләре, фельетоннар дөнья күрә. Мәктәп һәм мәдрәсә укытучыларына аерым игътибар бирелә: «Т.» г-тасы аларны яңа хакимият башлангычларын якларга чакыра. 1919 ның гыйнварында исеме «*Көч*» дип үзгәртелә.

**ТАРХА́Н**, 1) Хәзәр каганлыгында эре феодал (бәк); идарәче (каган) титулы. 2) Алтын Урдада, ул таркалганнан соң барлыкка килгән татар ханлыкларында өстенлекләр җыелмасы (төрле салымнардан азат ителү, хөкемгә тартылмау хокукы һ.б.), феодаль аксөякләргә, сәүдәгәрләргә, руханиларга, шундый хокукларга ия булучыларга бирелә. Хәрби-феод. аксөякләрнең «тарханлык» алганда өстенлекләре *сөйургал* тотучылар хокукына тиң диярлек. Аларга тарханлык хокукы хан исеменнән Т. ярлыгы бирү б-н ныгытыла (к. *Сәхибгәрәй хан ярлыгы*). Т.нар җәмгыятьтә аерым хөрмәткә лаек булганнар; бу татар халык мәкальләрендә чагылыш таба (мәс., «Ат яхшысы арканда, ир яхшысы тарханда»). 3) Урта гасырларда рус дәүләтендә хокукый өстенлек биргән актлар төре, документ («тарханно-несудимые грамоты») атамасы, алар феодалларның, шәһәр халкы яки һөнәрчеләрнең аерым корпорациясенең финанс һәм мәхкәмә иммунитеты күләмен билгелиләр. Т. дип ш.у. аерым өстенлекләргә ия булган, рус булмаган йомышлы катлау вәкилләрен дә атыйлар. Хәзерге вакытта «Т.» сүзе кеше исемнәре, фамилияләрендә, ш.у. топонимнарда (мәс., Олы Тархан авылы) очрый.

*Әд.:* У с м а н о в М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. К., 1979.

*М.Г.Госманов.*

**ТАРХА́Н** елгасы, Идел алдында, Бидәңге елгасының (Кылна, Зөя елгалары бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 18 *км*. Бассейнының мәйданы 93,7 *км*². Тәтеш р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Бессоново авылыннан 1 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Яңа Льяш Пүчинкәсе һәм Иске Колмәт авыллары янында. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы — 88 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. Т.ның 0,6 дан 6,7 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,32 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 85 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,015 *м*³/с. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

**ТАРХА́Н** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай авылыннан 28 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мәллә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 17 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — умартачылык. 1914 тә нигез салына. Оешкан көненнән Самара губернасының Бөгелмә өязе Әлки волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1920 дә — 144, 1926 да — 150, 1938 дә — 143, 1949 да — 126, 1958 дә — 127, 1970 тә — 97, 1979 да — 63, 1989 да — 13, 2002 дә — 12 кеше.

**ТАРХА́Н** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 15 *км* төньяктарак, Кече Сөлчә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 180 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, иткә терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөз ахырына кадәр нигез салына. Беренче исеме — Новопоселённая Тарханка. 1861 елгы реформага кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире (Иске Илтерәк авылын да кертеп) 3605 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Аксубай волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1859 да — 426, 1897 дә — 409, 1908 дә — 433, 1920 дә — 481, 1926 да — 375, 1938 дә — 475, 1949 да — 355, 1958 дә — 319, 1970 тә — 410, 1979 да — 357, 1989 да — 241, 2002 дә — 197 кеше.

**ТАРХА́Н** посёлогы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 29 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Арбор елгасы буенда. 2010 елда 1 кеше (татар) яши. 1928 дә Нөнәгәр авылы кешеләре нигез сала. Оешкан көненнән ТАССРның Арча кантоны Арбор волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1938 дә — 88, 1949 да — 90, 1958 дә — 122, 1970 тә — 70, 1979 да — 28, 1989 да — 17, 2002 дә — 6 кеше.

**ТАРХА́Н ИМӘНЛЕКЛӘРЕ́**, табигать истәлеге. Тәтеш р-нының Бессоново авылыннан көньяктарак урнашкан. Идел елгасының уңъяк ярындагы урман массивы (Тәтеш урманчылыгының Тархан участок урманчылыгы). 1972 елда билгеләнә. Мәйданы 882,3 *га*. Сабакчалы имән ареалының төньяк-көнчыгыш өлешендәге һәм гади корычагач ареалының көнчыгыш чигендәге Идел буе тау имәнлекләре участогы. Көньякка караган тау битендә урман типларының әзлекле алышынуы күзәтелә: очлы яфраклы өрәңгеле-сәрдәле юкәлекләр — юкәле-корычагачлы имәнлекләр — наратлыклар. Урман эчендә — чиклә-



Тархан имәнлекләре.

век куаклары, ш.у. өрәңге, юкә, күгән, урман алмагачы; үлән капламында сәрдә, исле сырмавык, күпьеллык зибык уты, май ландышы үсә. Хайваннар дөньясында ТРның Кызыл китабына кертелгән төрләр: бакыр кәлтә, гади кара елан, елга каракошы, соры ябалак, яшел тукран, кычыткан чыпчыгы, йоклач, исле матур коңгыз, болан коңгыз очрый. Ташка әверелгән башаяклы казылма моллюск (белемнит, аммонит) калдыкларын үз эченә алган мезозой утырмаларының ачылмалары булган яр буе өлеше фәнни әһәмияткә ия.

**ТАРХА́НОВ** (псевд., чын фамилиясе Гаффаров) Барый Шиһабетдин улы (5.11.1892, Сембер ш. — 1935, Казан), драма актёры, ТАССРның атказ. артисты (1926). Татар проф. театрына нигез салучыларның берсе. 1908 елдан «Сәйяр» труппасында. «Нур» труппасында, Казан, Оренбург, Троицк, Петропавел, Сембер татар театрларында эшли. 1922 дән Беренче татар дәүләт драма театры (Татар акад. театры) составында. Кабатланмас драматик һәм комик сәләткә ия Т., татар, рус һәм дөнья драматургиясе геройларын сәхнәдә гәүдәләндереп, зур образлар иҗат итә: Исмәгыйль («Галиябану», М.Фәйзи), Дивана («Хөсәен мирза», Ф.Бурнаш), Мисбах хаҗи («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин), Шуйский («Иоанн Грозныйның үлеме», А.К.Толстой), Бобчинский («Ревизор», Н.В.Гоголь), Свенгали («Трильби», Г.Г.Ге), Альтоум («Турандот», К.Гоцци), Миллер («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер) һ.б. Ф.Бурнашның актёр өчен махсус язган «Камали карт» пьесасы буенча куелган спектакльдә Т. иҗат иткән Камали образы театр сәнгатендә зур вакыйга буларак кабул ителә. Яшәү мәгънәсен бары тик байлык туплауда гына күргән һәм комсомол булып киткән балаларын аңларга теләмәгән тупас, үзсүзле авыл агае Камалиның аның заманы, ягъни хуҗалар заманының мәңгегә бетүенә төшенүен актёр ышандырырлык итеп гәүдәләндерә. Газаплы уйланулар аша, ниһаять, рев-ция идеяләренә төшенгән Мужик («Адашкан кыз», Ф.Бурнаш) ролендә Т. катлаулы психол. характер тудыра.

*Әд.:* Татар театры (1906–1926). К., 2003; Илялова И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; Арсланов М.Г. Татарское режиссёрское искусство 1906–1941. К., 1992. *И.И.Илялова.*

**ТАРХА́НОВ** Илдар Габдулла улы (14.2.1945, Казан), хокук белгече, юридик фән. д-ры (2003), проф. (2004), ТР һәм РФнең атказ. юристы (1995, 2006). Казан ун-тын тәмамлый (1973), шунда ук җинаять хокукы кафедрасында эшли; бер үк вакытта, 1986–92 елларда, юридик ф-т деканы урынбасары, 1992–2015 тә деканы. Хезмәтләре җинаять хокукы мәсьәләләренә, җинаять җаваплылыгын һәм җәзаны дифференциацияләү һәм индивидуальләштерү проблемаларына карый.


Хезм.: Замена наказания по советскому уголовному праву. К., 1982; Поощрение позитивного поведения в уголовном праве. К., 2001.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.


**ТАРХА́НОВ** Илдус Габдрахман улы (18.1.1950, Чистай р-ны Яуширмә а.), мәдәният эшлеклесе, филос. фән. канд. (2005), ТССРның, Кырым Респ-касының, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1991, 2003, 2004). Казан мәдәният ин-тын тәмамлый (1975). 1970–71 елларда Яуширмә авылы мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе. 1975–76 да Лениногорск Техника һәм мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе, 1976–79 да, 1982–83 тә директоры урынбасары. 1979–82 дә Лениногорск кинотеатрлар берләшмәсе директоры. 1983–92 дә Чаллы шәһәрендә: КамАЗ мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе (1985 кә кадәр), 1985–91 дә Халык депутатларының Чаллы шәһәр советы башкарма ком-тының мәдәният бүлеге мөдире. 1991 дән Казанда: «Евразия континенты» корпорациясенең башкарма директоры. 1993–99 да ТР мәдәният министры урынбасары, 1999–2005 тә — министры. 2005 тән ТРның Казакъстан Респ-касындагы вәкаләтле вәкиле, 2010 нан «Россотрудничество» федераль агентлыгы җитәкчесе урынбасары. Язмалары хәзерге мәдәниятнең бөтенлеге проблемаларына карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ТАРХА́НОВА** Флёра Габдрахман кызы (25.5.1947, Чистай р-ны Яуширмә а.), шагыйрә, прозаик, тәрҗемәче, филол. фән. канд. (2004), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2007). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1975), шунда ук эшли. 1990–95 елларда «Шәһри Казан», «Татарстан хәбәрләре» г-таларында тәрҗемәче (1994 тән тәрҗемәләр бүлеге мөдире). 1995–2007 дә ТР МК аппаратында: тәрҗемәче, 1996 дан әйдәп баручы референт, 1999 дан беркетмәләр бүлегенең баш киңәшчесе. 2007–09 да Казан ун-тының гамәли лингвистика һәм тәрҗемә теориясе кафедрасында укыта. «Синең кайнар сулышың» (1997), «Йөрәгемә яшерелгән серләр» (2001), «Яшьлек эзем калган сукмаклар» (2005) шигъри җыентыклары, «Язмышлар язылганда» (2007), «Хисләр дәрьясында» (2012) проза китаплары авторы. Т.ның иҗаты милләт язмышын кайгырту б-н сугарылган. Балалар өчен язган «Уңган кыз» (1997), «Серле дөнья» (2002), «Алтын уклар» (2007), «Карлыган белән Чия» (2013) китаплары кызыклы булулары, теленең гадилеге б-н аерылып торалар. «Өч каурый» әкияте буенча 2005 тә татар «Әкият» курчак театрында спектакль куела. «Сөю газабы, яки Ташлама мине» әсәре Татарстанда «Иң яхшы драма әсәрләре» конкурсында (2006) 2 нче урын ала. Т. шигырьләренә композиторлар Р.Ахиярова, Р.Яхин, Ф.Хатыйпов, Л.Батыр-Болгари, И.Тарханов тарафыннан музыка язылган. З.Фәтхетдинов, Г.Яхина, Л.Саттарова, казакъ язучысы Р.Отарбаев һ.б.ның әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. «Русча-татарча иҗтимагый-сәяси сүзлек» (1997) төзүче. ТАССР ЮС Президиумы, ТР Дәүләт Советы, ТР МК Мактау грамоталары, медальләр б-н бүләкләнә. ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләге лауреаты (2010).

*Әд.:* Зөлфәт. ...Диде сөйгән йөрәк // Мәйдан. 2002. № 5; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. 2 т.; Хасанова Ф. Развитие традиций восточного жанра газели и новаторство в творчестве Ф.Тархановой // Научный Татарстан. 2013. № 1.



Б.Ш.Тарханов.



И.А.Тарчевский.

**ТАРЧЕ́ВСКИЙ** Игорь Анатольевич (24.1.1931, Омск ш.), биохимик, үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (1965), РФА (1992; 1987 елдан СССР ФА академигы; 1981 дән мөхбир әгъза), ТР ФА академигы (1991), РСФСР, ТРның атказ. фән эшлеклесе (1981, 2006). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1954), шунда ук эшли, биохимия кафедрасын оештыручы һәм аның мөдире (1965–74, 1985–95), проф. (1967). 1974 тән РФА КГҮнең Казан биохимия һәм биофизика ин-тында: пигментлар һәм аксымнар метаболизмы лаб-ясе мөдире (1974–2001), директор (1975–92), баш фәнни хезмәткәр (1996 дан), аксым метаболизмы төркеме җитәкчесе (2006 дан). Казан химия-технол. ин-тында, Минск, Пущинск һ.б. ун-тларда лекция курслары укый. Россиянең бөек галимнәре К.А.Тимирязев (Мәскәү), С.П.Костычев (С.-Петербург ш.), Н.М.Сисакян (Мәскәү өлкәсенең Дубна ш.) истәлегенә багышланган укуларга лектор буларак чакырыла. РФА КГҮ Президиумы рәисе (1991–96), әгъзасы (1996 дан), РФА киңәшчесе (1996 дан); бер үк вакытта РФАнең А.Н.Бах исем. Биохимия ин-тында фитоиммунитет биохимиясе лаб-ясе мөдире (Мәскәү, 1996). ТР ФАне булдыруда актив катнаша, 1992–97 дән аның вице-президенты. Хезмәтләре үсемлекләр фотосинтезына, целлюлоза биосинтезына, матдәләр алмашуның табигый көйләгечләрен өйрәнүгә карый. Фотосинтез химизмын өйрәнүдә радиоактив изотоплар куллану Т.га корылык һәм үсемлек тереклегенең күп кенә башка тискәре шартлары йогынтысында фотосинтез продуктларының (углевод, органик һәм аминокислоталар) барлыкка килүендә һәм үзара бәйләнешендә мөһим үзгәрешләрне беренче булып табарга мөмкинлек бирә. Т. тарафыннан үсемлекләрнең кырыс климатик факторларга чыдамлыгын һәм патоген микроорганизмнарга иммунитетын булдыруның молекуляр нигезен тәшкил иткән сигнал системаларыннан торучы күзәнәкләрдә сигнал челтәре булу турында күзаллау эшләнә. Үсемлекләрдә аксымнар синтезын сигнал репрограммалау тикшеренүләре вакытында өстенлекле нәтиҗәләр алына. Күп кенә табигый һәм химик синтезлашкан кушылмалар тәэсирендә патоген микроорганизмнар үсешен тоткарлаучы антипатоген аксымнар һәм үсемлек күзәнәкләренең аларга тотрыклылыгын арттыручы аксымнар барлыкка килүе күренә, бу исә фитоиммунитетны көчәйтүче яңа буын саклагыч препаратлар булдыруга мөмкинлек бирә. Аэрокосмик тө-

шерү кулланып, зур мәйданнарда чәчүлекләрнең потенциаль продуктлылыгын билгеләү һәм селекция өчен мөмкинлекләр ачучы хлорофиллы фотосинтетик потенциал ярдәмендә фотосинтетик продуктлылыкка бәя бирүнең Т. тәкъдим иткән перспектив алымы киң кулланыш ала. Бөтенсоюз үсемлек физиологлары җәмгыяте вице-президенты, «Известия РАН» һәм «Физиология растений» фәнни ж-лларының мөхәрририят әгъзасы. РФАнең Физик-химик биол. бюросы әгъзасы, Глобаль климат һәм үсемлекләрдә экологик стресслар буенча ведомствоара координацион гыйльми совет рәисе, яңа технологияләр өлкәсендә Россия-Һиндстан программасы нигезендә фитобиотехнология буенча тикшеренүләр координаторы. РФАнең Д.Н.Прянишников исем. премия бирү ком-ты рәисе. Үсемлекләр физиологиясеннән кандидатлык диссертацияләре яклау буенча институтның Гыйльми советын җитәкли. СССР ВАК һәм РФ ВАКның биология фәннәре буенча эксперт советы әгъзасы була. РФ алдынгы гыйльми мәктәбенең күзәнәк сигнализациясе проблемаларын хәл итүгә багышланган грантларының фәнни җитәкчесе (1996–2009). Фотосинтетик продуктлылык (Казан, 1972), липидлар метаболизмы (А.Н.Гречкин б-н берлектә, Казан, 1991), үсемлек күзәнәкләренең сигнал системалары (Мәскәү, 2001; Казан, 2006) буенча Россиядә беренче симпозиумнар оештыручы. ТР ФАнең В.А.Энгельгардт (1999) һәм РФАнең А.Н.Бах (2002) исемендәге бүләкләре лауреаты. Казан ун-тының Мактаулы д-ры (2001). Халыклар Дуслыгы, 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», Почёт, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Т.ның шәкертләре арасында РФА академигы А.Н.*Гречкин* бар.

Х е з м.: Фотосинтез и засуха. К., 1964; Основы фотосинтеза. М., 1977; Катаболизм и стресс у растений. М., 1993; Хлорофилл и продуктивность растений. М., 2000 (автордаш); Метаболизм растений при стрессе. К., 2001; Сигнальные системы клеток растений. М., 2002; Cellulose: Biosynthesis and structure. B., 1991 (автордаш).

*Әд.:* С и д о р о в а Т. Соросовские профессора Казани. К., 1996; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**ТАРШНА́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 24 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. Даими яшәүчеләр юк. 17 йөз башына кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, башмак тегү, олаучылык б-н шөгыльләнә; читкә китеп эшли. 20 йөз башында Т.да мәчет (1887 дә төзелә), мәдрәсә, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 531,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Салкын Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 39 ир-ат; 1859 да — 333, 1897 дә — 381, 1908 дә — 446, 1920 дә — 357, 1926 да — 411, 1938 дә — 390, 1949 да — 222, 1958 дә — 120, 1970 тә — 88, 1989 да — даими яшәүчеләр юк.

**ТАРЫ́** (Panicum), кыяклылар семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 500 төре билгеле. Туган ягы — Кытай һәм Монголия. Б.э.к. 3000 нче елдан үстерелә. РФдә 8 төре бар. Татарстан терр-ясендә, башлыча, гади Т. яисә Т. (P. miliaceum) үстерелә, сабан тарысы, җылы яратучы, корылыкка чыдам үсемлек; кыргый хәлдә очрамый. Идел буе Болгар дәүләте чорыннан билгеле. Вегетация чоры — 60–90 көн. Нигездә, үзеннән-үзе серкәләнә. Тамыр системасы — чук тамыр, 1 *м* тирәнлеккә кадәр китә. Сабагы туры, ботаксыз, эче куыш, аз төкле, биеклеге 60–80 *см.* Яфраклары киң, ланцетсыман, озынлыгы 65 *см* га кадәр, киңлеге 3–4 *см*, өске өлеше бөгелгән. Чәчәк оешмасы — себеркәч, озынлыгы 7–10 *см* дан 30–40 *см* га кадәр, җәенке, салынкы, кысынкы һ.б. формада була. Җимеше — бөртекчә, шарсыман, озынча формада, кофе төсендә, ак, аксыл төстән кызыл, коңгырт сары, соры төскә кадәр була. Кара туфраклы, реакциясе нейтраль яисә ачылыгы аз булган соры урман туфракларында яхшы үсә. Иң яхшы элгәрләре — сызма, көзге культуралар, күпьеллык үләннәр. Яз көне яхшы җылынган туфракка тоташ рәтле ысул б-н (чәчү нормасы — 1 *га* га 30–40 *кг*, 3–5 *см* тирәнлектә) чәчәләр. Кисәү гөмбәсе авыруына каршы мәҗбүри агулауга мохтаҗ. Алдан чабып, теземнәргә салу ысулы б-н җыялар. ТРда чәчүлек мәйданы 1,9 мең *га* (2013), уңышы уртача 5 елга 1 *га* дан 21,6 *ц*. Бөртеге ярма һәм он итеп эшкәртелә. Тары ярмасы клетчаткасы аз булу б-н аерылып тора, составында аксым (10–16%), крахмал (70–80%), май (3–4%), шикәр (1,5–2,5%), шактый күләмдә минераль тозлар, микроэлементлар, витаминнар бар; балалар азыгында һәм диетик туклануда кулланыла. Бөртеген, кабыгын һәм саламын кошларга һәм хайваннарга азык буларак кулланалар. Корткычлары — тары черкие, сабак күбәләге. Авырулары — кисәү гөмбәсе, бактериозлар. ТРда чәчүгә «Кама» (1978), *«Казанское кормовое»* (1991), «Татарское красное» (1993), «Лучистое» (2003), «Бәхетле» (2012) сортлары рөхсәт ителгән.

*Әд.:* Возделывание проса в Республике Татарстан. К., 2001; Руководство по апробации сортовых посевов. К., 2002; Сельскохозяйственный энциклопедический словарь. М., 1989.

*Ф.З.Кадыйрова.*

**«ТА́СМА»**, химия пр-тиесе; киң ассортиментта продукция эшләүне тәэмин итүче үз технол. һәм житештерү базасы булган, РФдә һәм БДБдә бердәнбер яктылыкка сизгер тасмалар чыгаручы. Казанда урнашкан. Эшләүчеләр саны — 360 кеше (2015). 1933 елда 8 нче кинотасма ф-касы буларак төзелә башлый; 1958 дән химия з-ды, 1979 дан Казан «Т.» ЖБ, 1994 тән «Т.» холдинг компаниясе («Т.-Холдинг»), 2009 дан «Т.» АҖ. 1935–94 тә В.В.Куйбышев исемендә. 1936 да ф-каның укыту-тәҗрибә станциясендә беренче продукция — аклы-каралы позитив кинотасма эшләнә. 1940 та коллоксилин (тасманың нигезен тәшкил итә торган чимал) җитештерү башлана. Бөек Ватан сугышы елларында ф-ка составына Ленинград, Киев һ.б. шәһәрләрдән эвакуацияләнгән фотохимия пр-тиеләре дә керә, анда тасмаларның һәм плёнкаларның яңа төрләрен (ш.и. аэрофоторазведка өчен аеруча сизгер тасмалар, противогазлар өчен тирләми торган плёнкалар, рентген плёнкалары, миномётларның дары зарядларын урнаштыру өчен плёнка футлярлар) чыгару үзләштерелә, аларны житештерү күләме 3 тапкыр арта; фронтны кинофотоматериаллар б-н өзлексез тәэмин иткәне өчен Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә (1944). Сугыштан соңгы бишьеллык ахырына (1946–50) пр-тие үзенең проекттагы егәрлегенә — елына 150 млн. *м* тасма һәм плёнка житештерүгә ирешә. Шуннан соңгы елларда житештерү куәтләре даими киңәйтелә һәм модернизацияләнә, продукция күләме һәм аның ассортименты арта бара. 1950 елларда яктылыкка сизгер тасмалар һәм плёнкалар чыгаруның тулы технол. циклын үз эченә алган зур цехлар — эмульсия әзерләү, сиптерү, формалау цехлары һ.б. төзелә; Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү кинофотоин-ты ф-лы (к. *Казан фотоматериаллар институты*) ачыла. 1960 елларда, барлык тасмаларны да янмый торган триацетатлы нигезгә күчерү сәбәпле, целлюлоза триацетаты һәм серкә ангидриды әзерләүче күптонналы корылмалар төзелә. 1970 елларда илдә иң зур тавыш яздыру магнит тасмалары һәм илдә бердәнбер ферромагнит порошогы производстволары файдалануга тапшырыла. 1970–80 елларда күп кенә технол. процесслар механикалаштырыла һәм автоматлаштырыла, көмеш нитраты чыгымын киметү чаралары күрелә. «Т.» аклы-каралы һәм төсле (1950 дән) негатив, позитив, кайтарылма кино- һәм фототасмалар чыгара. Продукциянең күпчелек өлешен микрофильмлауда, мед. һәм сәнәгать рентгенографиясе, полиграфия сәнәгате, фототелеграфия, спектрография, осциллография, аэрография, астрография (ш.и. 1964 елда дөньяда беренче булып Айның күренми торган ягын төшерүдә кулланылган тасма), төш физикасы, криминалистика, тавыш яздыруда файдаланыла торган махсус тасмалар били. Авиация һәм транспорт машиналары төзелешендә кыйпылчыксыз пыяла, аккумуляторлар ясау өчен эшләнмәләр; басма платалар өчен коры фоторезист; химия, азык-төлек, фармацевтика, радиоэлектроника сәнәгатьләрендә кулланыла торган мембраналар һәм сыек тирәлекләрне бүлү фильтрларын житештерү оештырыла. Пр-тиедә кинофильмнарны күпләп тиражлау (күчереп язу) җайга салына. «Т.» продукциясенең бик күп төрләре СССРда һәм дөньяда бердәнбер булып санала һәм 1950 еллар уртасыннан 30 дан артык илгә чыгарыла. 1990 елга 400 гә кадәр исемдәге эшләнмә исәпләнә, елга 780 млн. п.м. кинофотоматериал, 2,6 млрд. *м* магнит тасмасы житештерелә (эшләүчеләр саны 9,2 мең кеше). 1990 еллардагы икътисади кризис шартларында продукция чыгару кискен кими. 1990 еллар ахыры – 2000 еллар башындагы кризиска каршы чаралар пр-тиенең финанс хәлен ях-




«Тасма». 1. Завод идарәсе бинасы. 2. Коллодий җитештерү бүлекчәсе.

шырту һәм җитештерүне диверсификацияләү мөмкинлеге бирә. Нәтиҗәдә, нефть чыгару сәнәгате өчен карбоксиметилцеллюлозалы җилем һәм төрле химик реагентлар чыгару үзләштерелә; космостан күзәтү чаралары өчен махсус фототасмалар һәм чит илләрдән кертелә торган үтә үзле целлюлоза триацетаты урынына катлаулы универсаль техник комплекс булдырыла; сизгерлек күрсәткечләре буенча барлык аналогларыннан өстен булган, үтә юка нигездәге һәм күп төрдәге рентген плёнкаларын серияләп җитештерү оештырыла; картографиядә куллану өчен лавсан һәм металл нигездәге плёнкалар эшләп чыгарыла башлый (РФ Хәрби көчләре Генштабының Хәрби-топография идарәсе өчен). 2007 дә файдаланылмый торган җитештерү мәйданнары кече һәм урта эшмәкәрлек базасы сыйфатында «Химград» технополисына бирелә.

2015 кә пр-тие ассортиментында — 50 дән артык төрдәге тасма һәм плёнка, ш.и. радиографик һәм флюорографик, җылылыкка сизгер, микрофильмнар төшерү өчен, парланмый торган, электр изоляциясе плёнкалары, тасмалар һ.б. 2014 тә азык-төлек продуктларын төргәкләү өчен кызудан аралаучы плёнкалар җитештерүгә керешелә. Соңгы елларда цифрлы типта язылган мәгълүматны теркәүнең заманча чараларын булдыру өлкәсендә эшләр алып барыла. Чыгарылган продукция халыкара ИСО 9001:2011 сыйфат стандартына туры килә. Продукция РФ базарына һәм якын чит илләргә чыгарыла. Чимал бирүчеләр арасында «Органик синтез», «Түбәнкаманефтехим», «Чаллы картон-кәгазь комбинаты» АҖләре, «Фотонхим» ҖЧҖ (Мәскәү өлкәсе Долгопрудный ш.), «КИФ» пр-тиесе (Казан), С.-Петербург компанияләре бар.

Пр-тие Казанның социаль үсешенә зур өлеш кертә: торак йортлар микрорайоны, Мәдәният йорты, 5 мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениесе, 3 социаль-пед. комплекс, стадион, хастаханә, поликлиника, 10 мең номерга ПТС һ.б. социаль-мәдәни һәм көнкүреш объектлары төзи. «Т.» хезмәткәрләре арасыннан 11 кеше — Ленин ордены, 7 кеше — Октябрь Революциясе, 66 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 62 кеше «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Пр-тиенең җитәкчеләре: В.Я.Барков (1932–34), В.Л.Штукатор (1934–36), В.П.Раковский (1936–37), И.М.*Шпаков* (1937–38), И.С.Смирнов (1939–40), Н.Н.*Сомов* (1940–51, 1952–61), Н.М.Изосимов (1951–52), А.К.Спиридонов (1962–69), В.О.Иванов (1970–74), Н.Х.*Йосыпов* (1974–86), В.Ф.Бобров (1987–88), Г.И.Трусенёв (1988–89), В.В.Филиппов (1989–96), Д.М.Исхаков (1996–98), Д.Ш.Моратов (1998–2007), Е.Е.Латинский (2007–2013), А.М.Гыйззәтуллин (2013 тән).

*Әд.:* Д я т л о в а А.М. «Тасма»: годы, люди, судьбы... К., 1996; Х а б и б у л л и н А.С. Испытание временем. К., 2008.

*А.М.Дятлова, С.Г.Белов.*

**ТАСМА́ СУАЛЧАННА́Р** (Cestoda), яссы суалчаннар классы. Олы затлары — паразитлар, кеше яки хайван эчәклегендә яшиләр. Гәүдәләре тасмасыман, озынлыклары берничә мм дан 25 *м* га кадәр, өч өлештән торалар: баш (сполекс), муен (үсү зонасы) һәм, гадәттә, буынтыклардан (проглотида) торучы стробила. Башларында берегү органнары — имгеч, ботрияләр, ыргаклы хортумчыгы һ.б. бар. Эчәклекләре (ашкайнату органы) юк, аның функциясен тегумент (гәүдә капламы) башкара. Т.с. — гермафродитлар. Һәр буынтыгында — 1–2 җенес комплексы, аларда бик күп күкәй (кайбер солитёрларда елына 60 млн. га кадәр) җитлегә. Үсеш циклы хуҗаларын алыштыруга бәйле. Личинкалар күкәйләрдә үсә, алар (тасмача корацидийлары) суга чыгалар яки арадаш хуҗага (солитёрларда, гадәттә, ул бер, тасмачаларда — ике) эләгәләр. Аеруча киң тасмача (к. *Тасмачалар*), *каешчалар, солитёрлар* (дуңгыз һәм үгез), *эхинококк* куркыныч.

*О.Д.Любарская.*

**ТАСМАЧАЛА́Р** (Diphyllobothiidae), Pseudophyllidea отрядыннан тасма суалчаннар. Олы затлары кеше һәм кайбер йорт һәм кыргый хайваннар эчәклегендә паразитлык итәләр (төрле авторлар мәгълүматлары буенча, кешедә 4–8 төре). Аеруча киң Т. (Diphyllobotium latum) — кеше организмында яшәүче иң зур паразит суалчаннарның (озынлыгы 2 дән 10 *м* га кадәр) берсе — күп таралган. Башы 2 имгеч буразналы (ботрияле). Буынтыклары 3 тән 4 меңгә кадәр. Олы буынтыкларның киңлеге озынлыгына караганда зуррак. Һәрбер буынтыгында — гермафродит җенес комплексы, аларда тәүлегенә 2 млн. күкәй җитлегә. Т.ның яшәү циклы хуҗасын алыштыруга нык бәйле. Үсеше өчен күкәйләре суга эләгергә тиеш. Алардан иректә йөзүче личинкалар (корацидийлар) чыга, алар исә ишкәгаяклы кыслачык (1 нче арадаш хуҗа) тарафыннан йотылырга мөмкин, аның куышлыгында личинка-процеркоид җитлегә. 2 нче арадаш хуҗа — ерткыч балыклар (Татарстан терр-ясендә, нигездә, чуртан, налим, алабуга, кыртыш), аларның эчке органнарында процеркоидлар 5–15 *мм* озынлыктагы плероцеркоидларга әвереләләр. Зарарланган, термик яктан начар эшкәртелгән яки җиңелчә генә тозланган балык ашап, соңгы хуҗа да аны йоктыра. Киң Т. тудырган дифиллоботриоз авыруларының кешедә аерым билгеләре беленми, әмма эшкә яраклылыкны югалту дәрәҗәсендә аппетит кочәя яки кими. Татарстанда дифиллоботриозлар гельминтозлар арасында 3 нче урынны алып тора, зоналы тупланыш характерында.

*Әд.:* К л е б а н о в с к и й В.А. Дифиллоботриозы // Гельминтозы человека. М., 1985.

*О.Д.Любарская.*

**ТАСМАЧЛА́Р** (Limenitis), нимфалидлар семьялыгыннан сукмар мыеклы көндезге күбәләкләр ыругы. 10 төре, Татарстан терр-ясендә 2 төре билгеле. Киң таралган төре — камилла Т. (L. camilla). Канат җәеме 40–60 *мм*. Канатларының өске ягы кара, ак бизәкле, аскы ягы аксыл көрән, зәңгәр һәм ак тимгелле. Июнь–августта очалар. Гусеницалары зелпедә һәм кар җиләгендә яши. Тирәк Т.ы (L. populi L.) киң таралган, әмма сирәк очрый. Зур күбәләк, канат җәеме 65–85 *мм*, кара көрән төстә, ак бизәкле, читләре кызыл чокырчыклы. Ата зат анасыннан тимгелләренең ваграк булуы б-н аерыла, ТРның көнбатыш районнарында ара-тирә канатлары бизәксез ата күбәләкләр дә очрый. Канатларының аскы ягы аксыл көрән, ак бизәкле, зәңгәр тимгелле. Гусеницалары тирәктә җитлегә. Июнь–июльдә, яфраклы һәм катнаш урман буйларында очалар. Камилла Т.ыннан аермалы буларак, тирәк Т.ы чәчәккә утырмый, пычракны, зарарланган агач кәүсәләреннән чыккан сокны, тизәк, хайван калдыкларын үз итә. Саклауга мохтаҗ.

*С.Г.Гордиенко.*

**ТАСПА́Р** (?–581), Төрки каганлык идарәчесе (572 дән). Уңышлы тышкы сәясәт алып бара. Т. идарә иткәндә Төрки каганлык иң көчле дәүләткә әверелә, Төньяк Кытайдагы Ци һәм Чжоу дәүләтләренең Төрки каганлыкка бәйлелеге көчәя.

**ТАССР НӘШРИЯ́Т ҺӘМ МАТБУГА́Т КОМБИНАТЫ́**, к. *Татарстан китап нәшрияты.*

**ТАССР ПАВИЛЬОНЫ́,** Мәскәүдәге Бөтенсоюз а.х. күргәзмәсендәге совет архит-расы истәлеге. Татар бизәлеш сәнгате элементларын кулланып, совет неоклассицизмы стилендә 1939 елда И.Г.Гайнетдинов һәм А.П.Ершов проекты б-н төзелә. А́ркалары һәм заллары, ачык ишегалды булган күргәзмә комплексы. 1954 тә И.Г.Гайнетдинов бинаның алгы һәм эчке якларын милли бизәкләр б-н шактый баетып, үзгәртеп кора. 1960 еллар башында сүтелә.



**ТАССРның 10 ЕЛЛЫГЫ́ ИСЕМЕНДӘГЕ́ МӘДӘНИЯ́Т САРАЕ́**, Казандагы совет архит-расы истәлеге. Казансу елгасының иске юлындагы биек ярына урнашкан. Арх. А.Э.Спориус проекты буенча төзелә. ТАССР төзелүгә 10 ел тулган көндә, 1930 елның 25 июнендә беренче нигез ташы салына. Төзелеш 1931 нең августында башлана һәм 1932 нең 7 ноябренә тәмамлана. Мәдәният сарае зур, кече, лекция, спорт залларын, ш.у. тир, бильярд, техника бүлмәләрен һәм балалар китапханәсен, түгәрәк эшчәнлеге өчен махсус балет залы булган бүлмәләрне эченә ала;



ТАССРның 10 еллыгы исем. мәдәният сарае. 1932. Архитектор А.Э.Спориус. 2005 фоторәсеме.

Мәдәният сарае каршында бакча ясала. Бинаның күләмле фәзаи композициясе ике һәм өч катлы күләмнәрнең көчле вертикаль доминанты — 1935 тә корылган парашют каланчасы б-н туры почмак ясап кисешкән кушылмада төзелә. Каланча парашют беркетеләчәк башнялы күтәрү краны рәвешендәге металл конструкцияле ачык мәйдан б-н төгәлләнә. Шома итеп штукатурланган кирпеч дивар фонында зур, квадрат диярлек тәрәзәләр аерылып тора. Ярымтүгәрәк баскыч почмаклары тоташ вертикаль пыяла б-н капланган. Махсус ишекләр бинаның клуб өлешенә (спорт һәм кече заллы) һәм зур залга илтә. Клубка керү юлына фасад яссылыгыннан чыгып торучы ишек күләме һәм аның өстендәге балкон аерым төс биреп тора. 1952 дә бинага реконструкция ясаганда зур тамаша залы шактый үзгәреш кичерә: ике яруслы ян ложалар кушып салына, фойе киңәйтелә, өстәмә ян ишекләр өстәлә. Бер үк вакытта зур тамаша залы үзәге буенча тамаша залының төп ишеге каршында ярымтүгәрәк касса вестибюле төзелә. Вестибюльнең батынкы фасады Казансу елгасының иске юлындагы биек ярны югары терраса б-н тоташтырган үзәк баскыч озынча түгәрәк мәйданчыгына илтә. 1933 тә, терр-яне төзекләндерү вакытында, кече зал ишеге каршында тимер-бетоннан бишпочмаклы йолдыз эченә урнаштырылган урак һәм чүкеч рәвешендәге фонтан куела. Креслода утыручы В.И.Ленин скульптурасы бакчаның үзәк өлеше булып тора. 1935–36 да бина артында революционер Роман Петров исем. парк төзелә («Петров паркы»). Бинаның үзәк өлешендәге үтеп йөрү аркасы фасад каршындагы бакчаны парк б-н тоташтыра. Төзелеш тәмамлануга, бинадагы бүлмәләрнең бер өлеше вакытлыча торак итеп файдалануга бирелә. 1941–44 тә биредә хәрби госпиталь эшли. Мәдәният сарае үзенең эшен 1945 тән яңадан башлап җибәрә. Зур залда спектакльләр һәм концертлар куела, кече залда кинофильмнар күрсәтелә. Сарайда төрле спорт секцияләре, китапханә, түгәрәкләр эшли. 20 йөз ахырында кризис нәтиҗәсендә ташландык хәлгә килә. 2008 елның октябрендә, көчле янгыннан соң, өлешчә сүтелә.

*С.Г.Персова.*

**ТАСТА́Р**, татар хатын-кызларының шарф рәвешендәге борынгы баш киеме. Хатын-кызның башын каплап торган 2 *м* га кадәр озынлыктагы, 40 *см* чамасы киңлектәге өйдә тукылган ак киндердән (төп өлеше) һәм аркага төшеп торган бизәкле баш-башлардан гыйбарәт. Т. озынлыгы буйлап ике яклап кызыл кайма үтә. Т. башка традицион баш киемнәре — чәчкап, яулык, башлык, шәл б-н бергә бөркәнелгән. Бигрәк тә мишәрләрдә, Касыйм татарларында, Мәлки керәшеннәрендә киң таралган. Т.ның баш-башларын чигү алымнарында һәм бизәкләрнең үзендә җирле үзенчәлекләр чагыла. Касыйм татарлары Т.ына — төрле төстәге тыгыз тамбурлы бизәкләр, Пенза губернасы мишәрләре Т.ына — «төсле кушып үрү» санаулы чигеш техникасы б-н эшләнгән геом. фигуралар, Сергач мишәрләре Т.ына — «корама» бизәк, Мәлки керәшеннәре Т.ына «чүпләм» ысулы б-н башкарылган, төрле төстәге җепләрдән тукылган вак бизәкләр хас. Әстерхан татарлары Т.ы үзенчәлекле (ак, еш кына челтәрле тукымадан тегелгән). Т. ике төрле була: бер төрлесен төрле яшьтәге хатын-кызлар бөркәнә; икенчесе — зур үлчәмлесе кәләш яки яшь хатын өчен тегелә (беренче тапкыр мондый Т. ир йортына күченгән вакытта бәйләнә). Т. башны һәм битнең аскы өлешен капларга мөмкинлек бирә. 20 йөз башында кулланыштан чыга.




Тастар бизәге. Тамбурлап чигү.

*Әд.:* Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; М у х а м е д о в а Р.Г. Татарская народная одежда. К., 1997.

**«ТАТАВТОДО́Р»**, автомобиль юлларын проектлау, төзү, төзәтү һәм карап тоту буенча Татарстандагы иң зур оешма. 1929 елда «Татдортранс» идарәсе буларак оештырыла. Күп тапкырлар исемен үзгәртә: Шоссе һәм грунтлы юллар, автотранспорт идарәсе (1931 дән), ТАССР Эчке эшләр халык комис-тының шоссе юллар бүлеге (1935 тән), ТАССР ХКС (МС) каршындагы Юл идарәсе (1938 дән), ТАССР МС каршындагы Юл һәм транспорт хуҗалыгы идарәсе (1953 тән), ТАССР МС каршындагы Автомобиль транспорты һәм шоссе юллар идарәсе (1954 тән), ТАССР МС каршындагы Автомобиль юлларын төзү һәм төзәтү идарәсе (1960–87). 1987 дән «Т.» проектлау-ремонтлау-төзү берләшмәсе (ПРСО), 2004 тән АҖ. 2008 дә «ПРСО «Т.», «ТР юл сервисы», «Татдорпроект» институты» АҖләре җирлегендә «Т.» АҖ оештырыла.

1930 елларда пр-тие структурасына респ-ка р-ннарында төзелгән беренче юлларны эксплуатацияләү һәм юллар төзү участоклары (ДЭУ, ДСУ) һәм машина-юл станцияләре (МДС) кертелә, бу оешмалар респ-ка карамагындагы юлларны төзү һәм ремонтлау эшләрен махсус финанслану яисә авыл халкын мәҗбүри эшләтү, атлар б-н тәэмин иттерү юлы б-н алып баралар. Җирле карамактагы юллар районга бирелә. Күпчелек эшләр кул хезмәте б-н, җирле чыганаклардан алына торган ташлы материаллар кулланып башкарыла. Ясалма корылмалар (күперләр, торбалар), башлыча, агачтан корыла. 1933–39 да респ-када таш һәм вак таш түшәлгән 1992 *км* юл төзелә, 1940 ка респ-ка карамагындагы 1200 *км* юлның 767 *км* ы, 8000 *км* җирле (өлкә карамагындагы юлларны кертеп) юлларның 1700 *км* ы каты түшәмә б-н каплана. Сугыштан соңгы елларда пр-тие халык хуҗалыгы өчен аеруча әһәмиятле юлларны яңарту эшләре алып бара (Казан–Чистай–Бөгелмә һ.б.), Куйбышев сусаклагычы астында калган зонада юлларны үзгәртеп кору б-н шөгыльләнә, респ-каның нефть чыгару р-ннарындагы юл төзү эшләрендә катнаша. Респ-ка күләмендәге юллар б-н берррәттән, пр-тие карамагына өлкә һәм җирле карамактагы юллар да күчә; яңа МДС, ДЭУ, ДСУлар һәм төзелеш материаллары б-н тәэмин итү өчен механикалаштырылган карьер хуҗалыгы оештырыла. 1956–57 дә беренче асфальт-бетон з-дын файдалануга тапшыру б-н (Лаеш р-ны Сокуры а. янында), асфальт юллар төзү башлана.

РСФСР ЮС Президиумының «Юллар төзү һәм ремонтлауда колхоз, совхозларның, сәнәгать, транспорт һ.б. пр-тиеләрнең һәм хуҗалык оешмаларының катнашуы турындагы» Указы (1959 ел 7 апр.) чыкканнан соң, пр-тие эшчәнлеген финанслау күләме күпкә арта, махсус юл төзү техникасы күбрәк файдаланыла башлый. 1959–65 тә гомуми кулланылыштагы каты түшәмәле 2876 *км* юл төзелә, 40 лап зур һәм уртача тимер-бетон күпер салына, 1500 дән артык тузган агач күпер һәм торба тимер-бетон нигездә ныгытып корыла. 1966 ел башына идарә карамагында респ-ка юллар хуҗалыгының 90% ы һәм күперләр хуҗалыгының 100% ы исәпләнә, болар — респ-ка, өлкә һәм җирле карамактагы 8778 *км* юл (ш.и. 4346 *км* каты түшәлмәле, шулардан 386 *км* — асфальт юллар), гомуми озынлыгы 37666 *м* булган 3719 күпер, ш.и. 3514 *м* озынлыктагы 152 күпер — озакка чыдамлылар. 1970–80 дә, Түбән Кама терр.-сәнәгать комплексы ихтыяҗларына бәйле рәвештә, Вятка (Нократ), Кама һ.б. елгалар аша күперләр һәм күперле кичүләр (мостовые переходы) төзелә, Чаллы–Зәй–Әлмәт, Алабуга–Әгерҗе юллары аркылы чыгу урынна-







«Татавтодор». 1. Кече Күккүз авылы янындагы күперне реконструкцияләү эшләре (Апас филиалы). 2. Асфальт-бетон заводы (Түбән Кама филиалы). 3. Минзәлә шәһәре аэропортында очу-төшү полосасын реконструкцияләү (Минзәлә филиалы).

ры б-н киңәйтелә, Чаллы–Минзәлә–Актаныш юлы яңартыла, күпсанлы кечкенә күперләр салына, нәтиҗәдә, барлык район үзәкләренә, күп кенә зур торак пунктларга, колхоз-совхозларга кадәр асфальт юллар салу мөмкинлеге туа. 1980 елларда «Т.»ның турыдан-туры катнашында сафка баскан мөһим объектлар: Казан–Чаллы автомобиль юлы (1972–83), Казан янында Идел елгасы аша күпер кичүе (1981–89), төньяктан Казан әйләнәсе автомобиль юлы (1980–90) һ.б.; 1990 елларда — Балык Бистәсе р-нының Саескан Тавы авылы янында Кама елгасы аша күпер.

1994 кә пр-тие структурасына Казанда — проектлау конторасы, җитештерү-технол. комплектлау һәм юллар эксплуатацияләү идарәләре, респ-каның район һәм шәһәрләрендә 45 юл төзү-төзәтү идарәсе һәм участогы керә. Эшләүчеләр саны 5 мең тирәсе кеше исәпләнә. Пр-тие респ-ка юл-транспорт инфраструктурасының күпчелек өлешенә хезмәт күрсәтә (ведомстволарга караган юллар һәм күперләрдән тыш).

2014 тә ТР терр-ясенең өчтән ике өлеше диярлек «Т.» эшчәнлеге зонасына карый. Пр-тие 7775,8 *км* озынлыктагы (ш.и. 499,7 *км* федераль) гомуми кулланылыштагы юлларга хезмәт күрсәтә. «Т.» асфальт түшәлмәсен, юл кырыйларын, юл инфраструктурасы элементларын карап тоту һәм агымдагы төзәтү, юлларга хәрәкәтне оештыру чараларын урнаштыру, 600 берәмлек күпер корылмасын төзек тоту эшләрен башкара. Ел саен 2700 *км* тирәсе юлга хәрәкәт сызыклары салына. «Т.» — авыл җирләрендә яңа асфальт юллар төзү һәм барлык торак пунктларга каты түшәмәле юллар сузу буенча президент программасын тормышка ашыручы оешма. 2014 тә Аксубай, Кайбыч, Лаеш, Кукмара, Минзәлә, Кама Тамагы, Сарман һ.б. р-ннарда юллар төзелә яки яңартыла. 2 федераль трассаны (М-7 «Идел» һәм Р-239 «Казан–Оренбург») тоташтырган 14,95 *км* озынлыктагы автомобиль юлы төзелеп бетеп, аның буенча хәрәкәт ачыла. 2014 тә «Т.» күче б-н автомобиль юлларындагы 163 объектны төзү, реконструкцияләү һәм төзекләндерү эшләре башкарыла; төзелгән һәм төзекләндерелгән төбәк юлларының гомуми озынлыгы — 332,6 *км*. «Т.» АҖгә 10 филиал һәм 27 участок керә, эшләүчеләр саны — 2330 кеше. Бүлекчәләрендә 1400 дән артык махсус техника: асфальт салгычлар, автогрейдерлар, катоклар, күп функцияле юл хезмәте машиналары, шнекороторлар, ресайклерлар б-н хезмәт күрсәтелә (2014). 2009 да бер үк вакытта Апас, Арча, Мамадыш, Аксубай, Минзәлә һәм Түбән Камада чит илдә җитештерелгән һәм егәрлеге 240 *т/сәг.* булган асфальт катнаштыргыч җайланмаларга нигезләнеп, 6 югары җитештерүчән асфальт з-ды сафка кертелә. «Т.» карамагында 11 берәмлек асфальт катнаштыргыч җайланма эшли (2014). «Т.»да 3Д-нивелирлау системасы нигезендә төзелеш техникасы б-н автоматлаштырылган идарә итү системасы, салкын регенерация, комташ-мастикалы асфальт-бетон актив рәвештә гамәлгә кереп бара. Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләренә дәүләт бүләкләре, ш.и. 50 кешегә РФ һәм ТР халык хуҗалыгының төрле өлкәләрендә атказ. хезмәткәр исемнәре бирелә.

Җитәкчеләре арасында: М.И.Дубков, А.Г.Морозов, И.В.Ярцев (1983–1997), Ф.Г.Гыйльмиев (1997–2001), И.Б.Шәйдуллин (2001–07), Ф.Ф.Якупов (2007–08), А.М.Шәймиев (2008 дән).

*Әд.:* Архитектурно-строительный комплекс Республики Татарстан: История, биографии, свершения, надежды. К., 2005.

**«ТАТАВТОТРА́НС»**, ТРда гомуми кулланылыштагы автомобиль транспортының дәүләт идарәче компаниясе. Тарихы Югары ХХС Үзәк автоинспекциясенең 1918 елда оештырылган Казан бүлегеннән башлана. 1921 дән Татарстанның үзәк җирле транспорт идарәсе, 1923 тән «Таттранспорт» АҖнең Татарстан конторасы, 1930 дан «Союзтранс» бөтенсоюз складлар һәм транспорт-экспедиция эше берләшмәсенең Татарстан өлкә конторасы, 1933 тән «Таттранспорт» Татарстан автомобиль-ат транспорты тресты, 1939 дан ТАССР ХКСның (МС) Автомобиль транспорты идарәсе, 1954 тән Татарстан автомобиль транспорты тресты, 1963 тән Татарстан автомобиль тресты идарәсе, 1983 тән «Т.» Татарстан төбәк автомобиль транспорты берләшмәсе, 1988 дән «Т.» Татарстан төбәк автомобиль транспорты ҖБ, 1991–95 тә һәм 1996–99 да «Т.» Татарстан респ-ка автотранспорт пр-тиеләре ассоциациясе, 1995 тән «Т.» холдинг компаниясе», 1999 дан «Т.» корпорациясе» АҖ.

1920 елларда пр-тие 1918 дә национализацияләнгән автомобиль транспортын һәм авторемонт пр-тиеләрен үзәкләштерүгә, аларны үстерү өчен төрле ведомстволардан акча җәлеп итүгә, системалы автомобиль хезмәтен оештыруга керешә. Казанда (1925), шәһәрара Казан–Лаеш (1930), өлкәара Казан–Йошкар-Ола (1932) беренче автобус маршрутлары ачыла. 1925–26 да автотранспорт б-н 270,6 мең пассажир һәм 24,5 мең *т* йөк ташыла. Алга таба автомобильләр б-н йөк ташу географиясе һәм автобус маршрутлары челтәре киңәя, респ-ка шәһәрләрендә һәм район үзәкләрендә пр-тиенең бүлекчәләре төзелә; автопарк системалы рәвештә яңа автомобильләр б-н яңартылып тора, хезмәт күрсәтү күләме арта. 1930 елларда җитештерү-техника базасы ныгытыла: 120 машиналык гараж, беренче бензин салу станциясе (Казан) төзелә; җирле йөк һәм пассажир ташуларга диспетчер хезмәте кертелә башлый; кадрлар әзерләү өчен укыту комб-ты оештырыла. 1936 да Казанда — йөк машиналарында; 1938 дә җиңел машиналарда такси хезмәте эшли башлый. 1937 дә пр-тиенең бүлекчәләре 17 гә, машиналар саны 117 гә (ш.и. 21 е районнарда) җитә; 123 мең кеше һәм 140 *т* йөк ташыла. 1941 гә 300 тирәсе автомобиль, ш.и. 80 автобус, 22 җиңел такси машинасы исәпләнә. Бөек Ватан сугышы елларында төп йөк машиналары паркы сугышка җибәрелә, автобуслар яралылар ташуга һәм эвакуация госпитальләре хезмәтенә алына. 1945 нең маендa Казанда даими пассажир автобуслары хезмәте яңадан торгызыла. 1947 дә автотранспорт конторасы булган район үзәкләрендә (Чистай, Чаллы, Бөгелмә) автобус маршрутлары ачыла.

1950 елларда гомуми кулланылыштагы автотранспорт көчле үсеш ала. Автотранспорт хуҗалыклары (АТХ) саны, ш.и. көньяк-көнчыгыш р-ннарда, күпкә арта, нефтьчеләрне ташу өчен махсус пассажир автоколонналары булдырыла. 1956 да Казанда беренче аерым такси-мотор автохуҗалыгы оештырыла. Ремонт-техника базасы ныгытыла: 1955 тә АТХларда агрегатлап-узеллап төзәтү (ремонтлау) алымы кертелә, вулканлаштырылган аппаратлар кулланыла башлый; 1957–59 да пр-тиегә Казандагы авторемонт остаханәсе, шиннар ремонтлау з-ды, техник хезмәт күрсәтү станциясе тапшырыла, Ютазы посёлогында шиннар ремонтлау з-ды ф-лы, Бөгелмәдә авторемонт остаханәсе ачыла. 1958 дә трест составына ТАССР Сәүдә министрлыгының зур автобазасы (830 машина) бирелә. 1961 гә трест бүлекчәләренең саны 35 кә җитә (АТХ һәм автоколонналар, ремонт һәм тәэминат пр-тиеләре, транс-

порт-экспедиция конторасы); 1950 дән башлап, хәрәкәт составы саны 155 тән (ш.и. 46 йөк машинасы, 43 автобус, 24 җиңел такси) 4610 (3174 йөк машинасы, 1018 автобус, 140 йөк һәм 278 җиңел такси машинасы) автомобильгә җитә. Автомобильләрдә йөк һәм пассажирлар ташуны үзәкләштерү, вак автопр-тиеләрне ябу процессы 1965 кә кадәр дәвам итә. Пассажир автобусы маршрутлары челтәре киңәя: 1954 тә 17 шәһәр һәм 17 шәһәрара автобус маршруты булса, 1956 да — 76 маршрут (гомуми озынлыгы 2807 *км*), 1970 тә 94 шәһәр, 119 шәһәр яны, 122 шәһәрара, 11 өлкәара маршрутка җитә. Респ-каның 8 шәһәрендә халыкка таксилар хезмәт күрсәтә. 1970 елларда пр-тиедә, илдә беренчеләрдән булып, автомобиль транспорты хезмәте б-н автоматлаштырылган идарә системасын, автоматлаштырылган диспетчер хезмәтен, автомобильләргә агрегатларын сүтмичә генә диагностика ясау гамәлгә кертелә башлый; Казанда хисаплау үзәге файдалануга тапшырыла. Перспектив үсеш планнарын эшләгәндә, аларны юл төзелеше проектлары б-н килештереп һәм пассажирлар хәрәкәтен системалы тикшереп төзү киң тарала. «Т.» нефть химиясе комплексы, КамАЗ пр-тиеләре төзүдә, респ-ка а.х.н үстерүдә зур роль уйный.

1990 га ЖБ составында 50 автотранспорт, сәнәгать, төзелеш, фәнни-тикшеренү, конструкторлык, укыту пр-тиесе һәм оешмасы, 35 меңнән артык хезмәткәр, 6900 тирәсе автобус, 6100 йөк машинасы, 1200 җиңел такси исәпләнә; елга 795,5 млн. пассажир һәм 44,9 млн. *т* йөк ташыла. Автотранспорт пр-тиеләрендә 16 диагностика комплексы, су әйләнешле 12 механикалаштырылган юдыру урыны, 78 электромеханик күтәрткеч, детальләр, узеллар һ.б.ны яңарту һәм әзерләү буенча 22 махсус участоктан файдаланыла. 1990 еллардагы икътисади кризис шартларында автопр-тиеләрне реформалау башлана; аларның бер өлеше мөстәкыйль пр-тиеләргә әверелә. 2000 елларда «Т.» составына кергән пр-тиеләрнең финанс хәлен җиңеләйтү автобус паркын тулысынча яңартырга, җитештерү-техник базасын үстерергә, яңа техника һәм технологияләр кертергә, пассажирлар ташуның нәтиҗәлелеген һәм куркынычсызлыгын күтәрергә, үз автоягулык салу станцияләре, газ ягулыклы котельныйлар, автоюдыргычлар, артезиан скважиналары төзергә мөмкинлек бирә. Респ-каның авыл районнарында маршрутлар челтәре тиз үсеш ала. 2014 тә «Т.» респ-ка районнарында һәм шәһәрләрендә 14 пассажир, йөк һәм катнаш автопр-тие акцияләренә ия була; аларда эшләүчеләрнең гомуми саны 1000 ләп кеше (ш.и. 450 дән артык машина йөртүче, 100 гә якын ремонтлау хезмәткәре) исәпләнә. Хәрәкәт составына 400 гә якын техника берәмлеге, ш.и. 390 автобус керә, алар гомуми озынлыгы 14,7 мең *км* булган 161 маршрутка хезмәт күрсәтә. 2014 тә ТР транспорт хезмәте күрсәтү базарында «Т.»ның өлеше 16% тан арта.

Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була: 1 кешегә — Соц. Хезмәт Герое, 50 ләп кешегә — РСФСР, ТАССР, ТРның атказ. транспорт хезмәткәре исемнәре бирелә; 9 кеше — Ленин ордены, 75 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 10 кеше — Халыклар Дуслыгы, 117 кеше — «Почёт билгесе», 19 кеше 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны ордены б-н бүләкләнә.

Җитәкчеләре арасында: Г.М.Шагаль, Р.Р.Рудольф, Ф.Ф.Гесс, А.В.Бегичев (1927–37), А.П.Обыдённов (1963–94), Д.В.Миңнуллин (2000 нән).

*Әд.:* Синицына К.Р., Тутаев М.З., Ахметов А.Н. Автомобильный транспорт Татарии: Страницы истории автомобильного транспорта общего пользования. К., 1987.

*Д.В.Миңнуллин, С.Г.Белов.*

**«ТАТАГРОПРОМПРОЕ́КТ»**, Казанда проектлау ин-ты, 1996 елдан ААҖ. 1986 елда «Татгипросельхозстрой» (1947) һәм «Татколхозпроект» (1961 дә нигез салына) ин-тлары җирлегендә оештырыла. Түбән Кама һәм Лениногорск шәһәрләрендә ф-ллары эшли. Совет хакимияте елларында ин-т, башлыча, посёлокларны, җитештерү, торак, җәмәгать биналарын һәм корылмаларын проектлаштыра. Шәпше (Биектау р-ны), Яңа посёлок (Тукай р-ны), Габишев (Лаеш р-ны) посёлокларының, Зәй, Чистай шәһәрләрендәге, Биектау р-нындагы Коркачык посёлокларындагы җитештерү-төзелеш комб-тларының һ.б.ның проектлары эшләнә. «Т.» — Татарстандагы әйдәп баручы проектлау оешмаларының берсе. Татарстанда һәм башка төбәкләрдә а.х. объектларының, торак пунктлардагы корылмаларның проектларын эшләү, торак биналар төзелешенә проект документларын әзерләү эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләреннән санала. «Т.» өстенлекле «Агросәнәгать комплексы үсеше» милли проекты кысаларында терлекчелек комплексларын яңарту һәм реконструкцияләү программасын тормышка ашыруда актив катнаша. Төп дәүләт заказчысы — ТРның Баш инвестиция-төзелеш идарәсе. Соңгы елларда «Т.» проектлары буенча Казанда һәм Чаллыда автомобильләр сату һәм техник хезмәт күрсәтү буенча дилер автоүзәкләре, Казанда «Союзшахтоосушение» ҖЧҖ бинасы, респ-каның 5 район үзәгендә спорт-савыктыру комплекслары, Ярославль өлкәсендәге Ростов шәһәрендә «VELUX» фирмасының мансарда тәрәзәләре җитештерү з-ды, Коркачык посёлогында «ВинербергерКирпич» кирпеч з-ды, Чистай шәһәрендә 2 нче микрорайон, Мәскәү өлкәсенең Щёлково шәһәрендә прокуратура бинасы төзелә; «Татарстан-Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе биналары комплексы, 5 район мәдәният йорты, хастаханәләр, мәктәпләр, балалар бакчалары реконструкцияләнә.

**«ТАТАГРОПРОМСТРО́Й»**, авылларда җитештерү һәм гражданлык объектлары төзелеше алып баручы күппрофильле оешма. Тарихы 1957 елда ТАССР р-ннарында колхоз пайлары хисабына колхозара төзелеш оешмалары (КТО) төзелүдән башлана. 1960 та алар җирлегендә Татарстан респ-касы колхозара төзелеш оешмалары берләшмәсе («Татмежколхозстройобъединение»; 1968 дән «Татколхозстрой») төзелә һәм ул а.х. тармаклары эшчәнлеген тәэмин итүче җитештерү объектларын төзүгә керешә. КТОларның матди-техник базасын ныгытуга, аларның төзелеш индустриясен үстерүгә зур игътибар бирелә. КТОлар респ-каның барлык р-ннарында да оештырыла, хәрәкәттәге механикалаштырылган колонналар, бораулау-шартлату эшләре конторасы, «Татколхозпроект» ин-ты һәм аның ф-ллары, Казан тимер-бетон эшләнмәләр з-ды, «Промстройматериалы» тресты, Себердә бернечә урман-сәнәгать хуҗалыгы, столярлык эшләнмәләре җитештерү буенча «стройдеталь» з-ды, Коркачык (Биектау р-ны) һәм Зәй сәнәгать-төзелеш комб-тлары, руда булмаган төзелеш материаллары комб-ты һәм аның причалы, механикалаштыру һәм җитештерү-технологик комплектлау идарәләре һәм аларның тимер юл челтәре, вак таш, ком һәм комлы вак таш катнашмасы чыгара торган махсус карьерлар, Казан, Түбән Кама һәм Лениногорскида төзелеш трестлары, автотранспорт пр-тиесе, сезонлы 35 кирпеч з-ды, «Дорколхозстрой» тресты, курслап укыту комб-ты төзелә. 1980 еллар башына эре а.х. комплексларын, торак йортлар, социаль-мәдәни һәм көнкүреш объектларын, колхозларның эчке автомобиль юлларын төзү, авыл торак пунктларын төзекләндерү буенча «Татколхозстрой» берләшмәсе респ-каның әйдәп баручы оешмасына әверелә (эшләүчеләр саны 13,5 мең кеше). 1986 да «Татколхозстрой» һәм «Татсельстрой» төзелеш идарәсе (1952 дә төзелә, 1953–63 тә «Татстрой», 1963–67 дә «Татсовхозстрой») җирлегендә Татарстан Респ-касының төзелеш буенча «Т.» кооператив-дәүләт берләшмәсе оештырыла (1987 дән «Т.» кооператив-дәүләт проектлаштыру-төзелеш берләшмәсе). Респ-када эшләүчеләр саны 20 меңнән арткан бердәм авыл төзелеше системасы формалаша. Тимер-бетон эшләнмәләр җитештерүнең еллык күләме — 350 мең $м^3$ дан, керамзитның — 150 мең $м^3$ дан, столяр эшләнмәләрнең — 200 мең $м^3$ дан, кирпечнең 100 млн. данәдән артып китә. Ел саен 260–280 млн. сумлык төзелеш-монтаж эшләре башкарыла. 1980 еллар ахырында «Т.» составында җиңел металл конструкцияләр һәм стеналар өчен яхшы җылыткычлы сендвич-панельләр эшләп чыгаруга көйләнгән пр-тие һәм елына 10 млн.нан 25 млн. данәгә кадәр кирпеч җитештерү куәтле 6 кирпеч з-ды төзелә. 1990 елларда эшләнмәләр әзерләүнең яңа технологияләре, гипстан һәм күзәнәкле бетоннан төзелеш материаллары гамәлгә кертелә; «Т.» бүлекчәләре *Тузган торакны бетерү программасын* һәм респ-ка районнарын газлаштыру программасын тормышка ашыруда, азык-төлек сәнәгате объектларын төзүдә актив катнашалар.

«Т.» Татарстанның авыл хуҗалыгын һәм авыл торак пунктларын үстерүгә зур өлеш кертә. 1960–2005 тә күп санда а.х. продукциясен саклау һәм эшкәртү пр-тиеләре һәм цехлары, 3 млн. баштан артыграк терлек өчен терлекчелек фермалары һәм комплекслары, 117 мең укучыга исәпләнгән мәктәпләр, 16 мең урынлык балалар бакчалары, 2,5 млн. $м^2$ мәйданда торак йортлар, 1200 урынлык хастаханәләр, сменага 2000 кеше кабул итүгә исәп-

ләнгән поликлиникалар, каты түшәмәле 750 *км* юл төзелә.

Күп кенә структур үзгәртеп корулардан соң «Т.»төзелеш эшләренең тулы технол. циклын үтәргә сәләтле компания булып кала, аның структурасына (ТР шәһәрләрендә һәм авылларында, ш.у. Удмурт Респ-касында) төзү-монтажлау оешмалары, проектлау ин-тлары, кирпеч з-длары, тимер-бетон эшләнмәләр җитештерүче төзелеш материаллары комб-ты, измә-бетон үзәге, агач материалларын әзерләү һәм эшкәртү пр-тиесе, тәрәзә һәм ишек блоклары, столяр эшләнмәләре җитештерү пр-тиесе, кадрлар әзерләү һәм квалификация күтәрү буенча уку-укыту комб-ты, ишекләр һәм тимер конструкцияләр эшләү цехлары булган җитештерү-комплектлау базасы керә. Эшләүчеләрнең гомуми саны 2 мең тирәсе кеше (2014). Төп заказчылары: «Главинвестстрой», «Татнефть» АҖ, ТР А.х. һәм азык-төлек министрлыгы, ТРның төзелеш комплексы оешмалары.

Югары нәтиҗәле һәм көндәшлеккә сәләтле эшчәнлеккә ирешкәне өчен «Т.» иң яхшы төзелеш оешмалары, төзелеш сәнәгате һәм индустриясе пр-тиеләре арасында үткәрелә торган Бөтенроссия конкурсы җиңүчесе дипломнары б-н бүләкләнә (2003, 2004). «Т.»да эшләүче 150 тирәсе кеше РФ һәм ТР халык хуҗалыгының төрле тармакларының атказ. хезмәткәре исемнәренә лаек була, 300 дән артык кеше орденнар һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Җитәкчеләре: К.И.Гордеев (1960–67), Т.И.*Айзатуллов* (1967–86), Т.Ш.Мөхетдинов (1986–87), А.М.Сәлахов (1987–90), И.М.Закиров (1990 нан).


*Әд.:* Татагропромстрой: события, люди. К., 2005.

**«ТАТАЗО́Т»**, к. «*Менделеевазот*».

**ТАТА́Р АВЫЛЛАРЫ́** (архит.), 18 йөзнең 2 нче яртысына кадәр елга яки ерымнарның бер яисә ике ягында үсеш алганнар. Гадәттә, мәчет җирлекнең түбән өлешендә, елга ярында төзелгән.


19 йөзнең 2 нче яртысында, шәһәр архит-расы, төзелеш нормалары һәм авыл җирлеген яңадан планлаштыру йогынтысында урам структурасы формалаша. Аңарчы авылларның архитектур-фәзаи корылышына урам, тыкрык һәм ябык тыкрыкларның тәртипсез рәвештә урнашуы хас була. Яңа төзелеш кагыйдәләре буенча мәчетләр төп урам б-н тыкрык кисешкән почмакта яки кечерәк кенә мәйданда корыла. Яңа типтагы җәмәгать һәм хуҗалык төзелешләре: кибетләр, фельдшерлык пунктлары, җәмәгать амбарлары һ.б. әлеге системага керә. Зур авылларда мәчетләрнең саны 2 дән алып 5 кә кадәр җитә. Кибетләр йортларның беренче катын билиләр, аерым бина рәвешендә йортның ян ягыннан урамга карыйлар яки сәүдә мәйданында төзеләләр. Җәмәгать амбарлары авыл читендә урнаша. Янгын каланчасы б-н каравыл өе буа яки елга тирәсендә була. Башка җәмәгать биналары, ш.и. мәчетләр, үзәк урамнардагы корылмалар б-н янәшә яки мәйданнарда урнаша.

20 йөз башында татар утарларының үзенчәлекләре формалаша башлый. Урта хәлле-




Татар авылы план-схемасы. Казан губернасының Олы Әтнә авылы: 1. Мәчет; 2. Каравыл өе; 3. Базар мәйданы; 4. Юлаучылар йорты; 5. Чишмә һәм коелар; 6. Зират.

ләрнең йортлары хуҗалык каралтыларыннан аерым, уеп бизәлгән койма б-н уратыла, кызыл сызыктан утар эченә 3–5 *м* кереп тора; йортның каршысында яки артында, еш кына утарның каршы ягында да бакча утыртыла. Сәнәгатьчеләр, сәүдәгәрләр һәм җир биләүчеләрнең эре торак-хуҗалык комплекслары кишәрлек үзәгендәге чарлаклы, ике катлы йортлардан һәм аның периметры буенча төзелгән аерым торак флигельләреннән һәм хуҗалык каралтыларыннан тора. Мондый утарларны еш кына аерым-аерым капкалы ак өйләр һәм хуҗалык каралтылары тәшкил итә. Ярлыларның утарларында, төбәктәге башка халыкларныкы кебек үк, үзенчәлек сизелми.



Татар авыллары утарларының архитектур-бизәлеш системасы.

Йорт һәм утарның архитектур-декоратив бизәлешендә шәһәр классик һәм традицион татар гамәли-бизәлеш сәнгате элементлары аралашып килә. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында татарларның утар һәм торак йорт бизәлешендә үзенчәлекле архитектур-декоратив система формалаша. Йортларның фронтоннарында декоратив куышлар ясала, тәрәзәләр уеп бизәлгән йөзлекләр б-н каймалана, фасадлар такта б-н ябыла, терәкләр һәм пилястралар б-н бизәлә, урам як коймасына декоратив рәшәткә өстәлә, капка уеп киселгән декор б-н бизәлә. Барлык элементлар да төрле төсләргә буяла. Татар авылларындагы йортлар бизәлешендә яшел, зәңгәр, алтынсу-сары, ак, сирәк кенә кызыл һәм зәңгәр төсләр аралаштырыла.

Авыллар төзелешенең бу этабында урамнарның түбәнге төрләре барлыкка килә: 19 йөзнең 2 нче яртысында һәм, башлыча, ахырында төзелгән, утарлары дөрес конфигурацияле һәм йортлары кызыл линиядә салынган олы юллар (элегрәк дәрәҗәсез һәм торакны урнаштыру өчен җайсыз саналган); чикләре утарның түрендәге йортлар каршында корылган рәшәткәле тоташ коймалар, капкалар һәм хуҗалык каралтыларының тоташ диварлары б-н билгеләнгән, үзәктә һәм елга буенда урнашкан борынгы урамнар; үзәктәге борынгы урамнардан корылма түрендәге утарларга илтүче ябык тыкрыклар; бары тик коймалар һәм хуҗалык корылмаларының тоташ диварлары б-н ясалган һәм урамнарны бәйләп торучы коридор-тыкрык кебек урамнар. Казан арты, аннары Кама алды авылларында формалашкан татар йортлары һәм утарларының архитектур-фәзаи корылышы һәм архитектур-декоратив бизәлеш системасы милли төсмер буларак кабул ителә һәм шәһәрләрдәге татар бистәләре, ш.у. Идел алды һәм Кама аръягындагы татар авыллары төзелешләрендә рев-циягә кадәр генә түгел, совет чорында да чагылыш таба. Утарлар һәм биналар корылышы һәм бизәлешенең кайбер элементлары хәзерге вакытта да саклана.

*Әд.:* Н а д ы р о в а Х.Г. Традиции в архитектуре Татарстана и ислам // Исламское искусство в Волго-Уральском регионе. К., 2002; ш у л у к. Мечети в архитектурно-пространственной структуре татарских селений Среднего Поволжья XVIII — начала XX веков // Татарские мусульманские приходы в Российской империи: Материалы Всерос. науч.-практ. конф. К., 2006.

*Х.Г.Надыйрова.*


**ТАТА́Р АКАДЕ́МИЯ ТЕА́ТРЫ** (Г.Камал исем. Татар дәүләт акад. театры), Казанда. Татар театр сәнгате һәм татар драматургиясенең формалашуы һәм үсешендә мөһим роль уйнаган бик күптәннән эшләп килүче татар проф. театры. 1906 елда Казанда татар телендә халык алдында беренче тапкыр театраль тамашалар б-н чыгыш ясый башлый. 1920 гә кадәр ширкәтчелек принципларында оешкан хосусый антреприза сыйфатында эшли. 1920 дә ТАССР Мәгариф халык комис-ты карары нигезендә элекке «Сәйяр», «Нур», «Ширкәт» һ.б. труппа актёрлары катнашында Беренче татар дәүләт драма труппасы оеша. 1921 дә труппа Беренче татар дәүләт театры дип үзгәртелә һәм үрнәк театрлар исәбенә кертелә, аңа элекке Сәүдәгәрләр клубы (хәзер Островский урамындагы Яшь тамашачылар театры (ТЮЗ)) бинасы бирелә. 1922 нең 8 ноябрендә, бинаны үзгәртеп корганнан соң, театрны ачу тантанасы уза (Ф.Бурнашның «Җирсезләр» пьесасы буенча спектакль күрсәтелә). 1926 га кадәр төрле исемнәрдә чыгыш ясый: «Кызыл Октябрь исем. Беренче татар дәүләт драма театры», «Октябрь революциясе исем. татар театры»; 1926 да, нигез салынуына 20 ел тулу уңаеннан, ТАССР Халык Комиссарлары Советы карары б-н акад. театры исеме бирелә; 1939 дан хәзерге исемдә. 1927 дә — ярты сезон дәвамында *Казан Зур драма театры* бинасында, 1928 нең февраленнән — элекке Кызыл армия сараенда (хәзер Татар драма һәм комедия театры бинасы), 1986 дан үзенең яңа бинасында эшли. Тормышны төрле яклап яктыртырга омтылган реалистик театр сыйфатында оеша. Әһәмияткә ия үзенчәлекле яклары: демократик юнәлештә булуы, хезмәт кешесенә теләктәшлек белдерүе, үткән заманнардагы югары сыйныфлар һәм дин әһелләренең җитешсезлекләрен һәм наданлыкларын фаш итүе. Театр үсешенең башлангыч чорында (1906–18) репертуар, нигездә, алдынгы фикерле, халыкта милли үзаң уятырга, аны мәгърифәтле итәргә, аңарда рухи яңарыш булдырырга омтылган татар драматурглары Г.Исхакый, Ф.Халиди, Г.Камал, Г.Коләхмәтов, С.Рәмиев, Ф.Сәйфи-Казанлы, Ф.Әмирхан, И.Богданов пьесаларыннан төзелә. Төгәл тормышчан материалга нигезләнгән драматургия актёрларга реалистик башкару манерасын үзләштерергә, геройлар кылган гамәлләрнең психол. сәбәпләрен эзләргә ярдәм итә. Репертуарны А.Н.Островский, Н.В.Гоголь, А.П.Чехов, С.А.Найдёнов, М.Горький пьесалары б-н тулыландыру, сәхнәгә кую эшенә рус актёрлары Н.Зимовой, Н.В.Михаленко, А.В.Загорский, М.А.Громовны җәлеп итү сәхнәдә реализмны раслауга этәргеч бирә.

1920 еллар театрның стационар репертуарын формалаштыру, даими труппа төзү чоры була. Театр б-н чор таләпләрен нечкә тоемлаучы драматург, актёр, реж. К.Тинчурин җитәкчелек итә. Театр тирәсендә яшь авторлар (М.Фәйзи, Ф.Бурнаш, Г.Ибраһимов, Ш.Усманов, Һ.Такташ, М.Гафури, Ә.Рахманкулов) төркеме оеша. Сезон дәвамында гел бер үк тамашачы өчен бер урында эшләү зарурлыгы яңадан-яңа сәнгатьчә сурәтләү формалары һәм чаралары табуны, үзенчәлекле сәхнәләштерү культурасын үзләштерүне таләп итә; режиссура тагын да әһәмиятлерәк була башлый. К.Тинчурин б-н беррәттән актёрлар М.Мутин, Ш.Шамильский, К.Шамил, М.Мәһдиев, З.Солтанов та режиссёрлык эше б-н шөгыльләнә башлый, сәхнәгә кую эшенә рус режиссёрлары Л.В.Развозжаев, Ю.В.Соболев, А.М.Кречетов; татар режиссёрлары Г.Девишев, Г.Исмәгыйлев, С.Булатов, соңрак Мәскәүдә махсус проф. белем алган Ш.Сарымсаков тартыла. Бер үк вакытта актёрлар әзерләү мәсьәләсе дә хәл ителә. 1922 дә З.Солтанов башлангычында Татар театр техникумы оеша (1923 нең 1 гыйнварында рәсми рәвештә ачыла), белем бирергә татар һәм рус театрлары актёрлары чакырып алына. Техникумны тәмамлаган кайбер актёрлар (Р.Ишморат, Х.Сәлимҗанов, К.Тумашева) режиссёрлык белгечлеге дә алып чыга.

1920–30 елларда совет театрында реалистик һәм формалистик юнәлешләр тарафдарлары арасында көчәеп киткән бәхәсләр татар театрын да читләтеп үтми. Т.Гыйззәтнең «Наёмщик», В.М.Киршонның «Рельслар гөрелдәгәндә» («Рельсы гудят», икесе дә — 1928), Н.Галимовның «Казан өчен көрәш» (1929), Г.Минскийның «ОДВА» (1931) пьесалары буенча С.Вәлиев-Сульваның сәхнә алымнары һәм эффектларыннан мул файдаланып куйган спектакльләре төрле караш уята. К.Тинчурин исә «Җир уллары трагедиясе» (Һ.Такташ), «Бай кызы» (Ш.Усманов), «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш; барысы да — 1922), ш.у. үзе язган «Беренче чәчәкләр» (1921), «Соңгы сәлам» (1922), «Сүнгән йолдызлар», «Казан сөлгесе», «Американ» (барысы да — 1924), «Зәңгәр шәл», «Җилкәнсезләр» (икесе дә — 1926) әсәрләре буенча куйган спектакльләрдә катгый рәвештә реалистик ысулга таяна. Г.Девишев тарафыннан куелган «Директор Җәмилов» (Г.Ку-



Г.Камал исем. Татар академия театры.



**Татар академия театры.** Г. Камал исем. Татар акад. театры спектакльләреннән күренешләр: 1. «Чаткылар», Т. Гыйззәт. 1934; 2. «Хуҗа Насретдин», Н. Исәнбәт. 1970; 3. «Отелло», У. Шекспир. 1953; 4. «Җилкәнсезләр», К. Тинчурин. 1958; 5. «Тукай», Ә. Фәйзи. 1966; 6. «Дошманнар», М. Горький. 1963; 7. «Кол», Г. Фигейредо. 1967; 8. «Американ», К. Тинчурин. 1969; 9. «Ташкыннар», Т. Гыйззәт. 1977; 10. «Банкрот», Г. Камал. 1979; 11. «Моңлы бер җыр», Т. Миңнуллин. 1981; 12. «Яшь йөрәкләр», Ф. Бурнаш. 1985; 13. «Зәңгәр шәл» К. Тинчурин. 2011; 14. «Хуҗа Насретдин» Н. Исәнбәт. 2014.

туй, 1926), «Боз астында дулкын», «Җиһан тетрәгәндә» (Ә.Т.Рахманкулов, икесе дә — 1926), «Хөсәен мирза» (Ф.Бурнаш, 1927), «Фетнә» («Мятеж», Д.А.Фурманов; 1929), «14–69 нчы бронепоезд» («Бронепоезд 14–69», В.В.Иванов; 1929), «Галиябану» (М.Фәйзи, 1929) спектакльләре югары сәхнәләштерү культурасы, төгәл режиссура б-н аерылып торалар.

Актёрлар б-н пед. эшчәнлек алып барыла, К.С.Станиславский системасы өйрәнелә, бу үз чиратында актёрлык осталыгын үстерүгә, труппа составын ныгытуга булышлык итә. Татар театр техникумын 1926 да тәмамлаган Р.Ишморат, Х.Сәлимҗанов, Г.Булатова, Г.Нигъмәтуллина, Х.Кәтиев, Г.Кайбицкая артыннан театрга техникумны 1928–30 елларда тәмамлаган Г.Таһиров, Н.Кальметова, Г.Ибраһимова, Г.Зыятдинов һ.б. килә. Ш.Шамильский, Н.Таждарова, М.Мутин, З.Солтанов, Ф.Ильская, К.Шамил, Г.Болгарская,

Камал III зур сәхнә осталары булып җитәләр. К.Тинчурин куйган «Кандыр буе» (К.Тинчурин, 1932), «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш, 1934), Г.Исмәгыйлев куйган «Профессор Мамлок» (Ф.Вольф, 1935), «Салют, Испания!» (А.Н.Афиногенов, 1936), «Чаткылар» һәм «Ташкыннар» (Т.Гыйззәт, 1936, 1937), Ш.Сарымсаков куйган «Шәмсекамәр» (М.Әблиев, 1938), «Тукай» (Ә.Фәйзи, 1939) спектакльләре респ-каның мәдәни тормышында зур вакыйга буларак кабул ителәләр.

Формализм турында 1936 да башланган бәхәсләр, әдәби бәхәсләр чиген узып, фаҗигале нәтиҗәләргә китереп җиткерә. К.Тинчурин, Ш.Усманов, М.Мутин, Ф.Сәйфи-Казанлы, Г.Ибраһимов, Ф.Бурнаш, Ә.Т.Рахманкулов репрессияләргә дучар ителәләр, пьесалары репертуардан төшерелә һәм аларны сәхнәгә кую тыела. Режиссёрлар Г.Исмәгыйлев, С.Булатов, Г.Ильясов театрны ташлап китәргә мәҗбүр булалар.

Бөек Ватан сугышы елларында театр сәнгате илне фашист баскыннарыннан саклау мәнфәгатьләренә буйсындырыла. Репертуарда төп урынны тамашачыда патриотик хисләр уятучы пьесалар ала. Бу елларда дөнья күргән аеруча игътибарга лаек спектакльләр: Ш.Сарымсаков куйган «Таймасовлар» (Т.Гыйззәт, 1941), «Тукай» (Ә.Фәйзи, 1942), «Рус кешеләре» («Русские люди», К.М.Симонов, 1942); «Идегәй» (Н.Исәнбәт, 1941; реж. Е.Г.Амантов), «Мәрьям» (Н.Исәнбәт, 1943; реж. Ш.Шамильский), «Миңлекамал» (М.Әмир, 1944; реж. Х.Уразиков). Аларда сугыш вакыйгалары б-н бергәттән ул еллардагы авыл тормышы да гәүдәләнә. Г.Ибраһимова, Р.Җиһаншина, Г.Булатова кебек актрисалар авыл кызы Мәрьям һәм колхоз рәисе Миңлекамалның героик образларын иҗат итәләр. «Король Лир» (У.Шекспир) һәм «Яшенле яңгыр» («Гроза», А.Н.Островский; икесе дә — 1944, реж. В.М.Бебутов), «Чаткылар» (Т.Гыйззәт, 1944; реж. Ш.Сарымсаков) спектакльләре зур театраль вакыйгага әверелә. Театр актёрлары һәм режиссёрлары концерт бригадалары составында хәрәкәттәге армия сугышчылары каршында чыгышлар ясыйлар, госпитальләрдә һәм эвакуация пунктларында шефлык эшендә актив катнашалар.

1940 елларның 2 нче яртысыннан театр сәхнәсендә конфликтсыз драматургия тамыр җәя, һәм бу иҗат атмосферасына, актёрлар һәм режиссёрларның осталык дәрәҗәләренә тискәре йогынты ясый. Ул елларда сәнгати кыйммәте түбән, төссез спектакльләр янында җитештерү мәнфәгатьләре арткы планга күчкән, беренче урында үзенең уй-хисләре, күңел кичерешләре б-н шәхес торган «Тормыш җыры» (М.Әмир, 1947; реж. К.Тумашева), «Зифа» (Н.Исәнбәт, 1954; реж. Х.Уразиков), «Беренче мәхәббәт» (Х.Вахит, 1960; реж. Р.Бикчәнтәев) спектакльләре театр дөньясында якты күренеш була. 1957 дә театр Мәскәүдә узган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында катнаша. Әлеге мөһим вакыйгага әзерлек һәм үзәк вакытлы матбугатның «Ташкыннар» (Т.Гыйззәт), «Хуҗа Насретдин», «Зифа» (Н.Исәнбәт), «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин), «Миңлекамал» (М.Әмир), «Король Лир» (У.Шекспир) спектакльләренә һәм Х.Әбҗәлилов, Г.Булатова, М.Сульва, Камал III, Г.Камская, Х.Уразиков, Ф.Ильская, В.Минкина, Г.Шамуков, Ф.Халитов кебек актёрларга биргән югары бәясе театрның кыска вакытлы күтәрелешенә булышлык итә. 1950 дә сәхнәгә Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тының (ГИТИС) татар студиясен тәмамлаган яшь актёрлар Ш.Әсфәндиярова, Р.Бикчәнтәев, Г.Камалова, Д.Ильясов, А.Галиева, П.Исәнбәт, Г.Хөсәенов, А.Хәйруллина, А. һәм Ш.Харисовлар, яшь драматурглар Х.Вахит, Ш.Хөсәенов, А.Гыйләҗев, И.Юзеев, Ш.Шаһгали килә; акланган авторлар К.Тинчурин, Ф.Бурнаш, Г.Ибраһимов әсәрләре кире кайтарыла. Шулай да 1965 нең язында РСФСР Мәдәният министрлыгы һәм Бөтенсоюз театр җәмгыяте тарафыннан җибәрелгән Мәскәү тәнкыйтьчеләре төркеме репертуарның ярлылыгын, уйнау манерасының искергәнлеген, татар театрында аңлаешлы сәнгать сәясәтенең юклыгын билгеләп үтә. 1966 ның язында баш режиссёр итеп М.Х.Сәлимҗанов билгеләнә. Ул килү б-н, театр үсешендә яңа этап башлана, спектакльләрдә әйдәп баручы рольне режиссура башкара; актёрлар б-н эш, образларның психол. эшләнеше режиссёрның уй-теләгенә ярашлы рәвештә, ул күзаллаган рәсемгә катгый туры китереп алып барыла. Заманча уйнау ысулын тормышка ашыруда М.Х.Сәлимҗанов 1961 дә М.С.Щепкин исем. Югары театр уч-щесен (Мәскәү) тәмамлаганнан соң труппага килеп кушылган яшьләр төркеменә — Ф.Әхтәмова, Н.Ихсанова, Г.Исәнгулова, Р.Таҗетдинов, Н.Дунаев, Ә.Шакиров, Р.Шәрәфиевләргә, ш.у. труппаның нигез өлешен тәшкил иткән урта буын актёрлардан Ш.Биктимеров, Н.Гәрәева, И.Баһманов, Ш.Әсфәндиярова, Р.Бикчәнтәев, Н.Әюпов, Х.Җәләлов, Д.Нуруллиналарга таяна. 1970–90 еллар дәвамында театр труппасы Ленинград театр, музыка һәм кинематография ин-тын, М.С.Щепкин исем. театр уч-щесенең икенче татар студиясен, Казандагы театр уку йортларын тәмамлаган актёрлар б-н тулылана. Театрга яшь режиссёрлар Р.Хаҗиәхмәтов, Ф.Бикчәнтәев, Д.Сираҗиев, Р.Фазлыев килә. Театр тирәсендә Т.Миңнуллин җитәкчелегендә драматурглар төркеме оеша, репертуарга Р.Батулла, З.Хәким, Р.Хәмид, Ю.Сафиуллин, Д.Вәлиев пьесалары кертелә. 20 йөзнең соңгы чирегe дәвамында театрда хәзерге заман драматурглары пьесаларыннан, ш.у. татар драматургиясенең классик мирасыннан төзелгән зур милли репертуар оеша. М.Х.Сәлимҗанов куйган «Миркәй белән Айсылу» (Н.Исәнбәт, 1966), «Американ», «Зәңгәр шәл», «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин, 1969, 1970, 1971), «Әни килде» (Ш.Хөсәенов, 1970), «Әлдермештән Әлмәндәр», «Моңлы бер җыр» (Т.Миңнуллин, 1976, 1981), «Өч аршын җир» (А.Гыйләҗев, 1987), «Агай-эне — ак мыек», «Бирнәсез кыз», «Җимерелгән бәхет» («Свои люди — сочтёмся», 1972; «Бесприданница», 1983; «Светит, да не греет», А.Н.Островский, 1993), «Баскетболист» (М.Гыйләҗев, 2002) спектакльләре хисләр чынлыгы б-н театральлекнең, характерлар үстерелешенең катгый эзлеклелеге б-н романтик күтәренкелекнең табигый үрелеп баруы ягыннан билгеләп үтелә, респ-каның театр тормышында зур бер вакыйга буларак кабул ителә, киң җәмәгатьчелек тарафыннан танылу ала һәм театрны илнең әйдәп баручы милли театр коллективлары рәтенә чыгара. Реж. П.Исәнбәт сәхнәгә чыгарган «Кол» («Эзоп», Г.Фигейредо, 1967), реж. Ф.Бикчәнтәев куйган «Бичура» (М.Гыйләҗев, 1989), «Ромео һәм Джульетта» (У.Шекспир, 1991) спектакльләре дә театрның зур казанышы була. Театрның Мәскәү, Ленинград (С.-Петербург), Россиянең башка шәһәрләрендә, Урта Азия, Әзәрбайҗан шәһәрләрендә узган даими гастроль чыгышлары, Германия (1996), Финляндия (1997, 2000, 2002), Төркия (1999, 2003, 2004), Англиядә (2007) узган халыкара театр фестивальләрендә актив катнашуы аңа халыкара танылу китерә, дөньяви театраль процессның тигез хокуклы катнашучысы итә.

2002 дән театрның сәнгать җитәкчесе итеп Ф.Бикчәнтәев билгеләнә. Искәндәр Хәйруллин, Р.Бариев, Л.Хәмитова, М.Габдуллин, Л.Рәхимова, Н.Хәйруллина, Ф.Сафин, М.Шәйхетдинова, Ф.Җиһанша кебек яшь, сәләтле актёрлар тырышлыгына таянып, ул нечкә психологизм б-н сугарылган, поэтик метафораларга һәм импровизациягә бай шактый спектакльләр иҗат итә. Ул куйган «Хушыгыз!», «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин; 1993, 1995), «Җирән чичән белән Карачәч сылу», «Гөлҗамал» (Н.Исәнбәт; 1999; 2007), «Кара чикмән» («Чёрная бурка», Г.Хугаев; 2002), «Телсез күке» (З.Хәким, 2004) спектакльләре халык мәхәббәтен казана. Болардан тыш театр сәхнәсендә «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин), «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш), «Банкрот» (Г.Камал), «Курчак туе» (Р.Хәмид), «Мулла», «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин), «Хан кызы Турандык» («Принцесса Турандот», К.Гоцци), «Мәхәббәт FM», «Әрем исе» (И.Зәйниев), «Искән җилләр көенә» (З.Хәким), «41 нең арбалы хатыннары» (З.Зәйнуллин), «Ут күршеләр» (С.Юзеев), «Сөясеңме, сөймисеңме?» (Ф.Бүләков), «Үлеп яратты» (Р.Зәйдулла), «Минем исемем Кызыл» («Меня зовут Красный», О.Памук), «Ричард III» (У.Шекспир), «Хуҗа Насретдин» (Н.Исәнбәт), «Һавалы биюләр» (С.Юзеев), «Исәнме, улым» (Б.Абдураззаков), «Дон Жуан» (Ж.-Б.Мольер), «Әлли-бәлли-бәү» («Әниләр һәм бәбиләр» пьесасы үрнәгендә, Т.Миңнуллин), «Көтәм сине...» (И.Зәйниев), «Бармы ришвәттән дәва?..» (З.Хәким) һ.б. спектакльләр зур уңыш б-н бара. Театр чит илләрдә, ТР һәм РФ шәһәрләре һәм районнары буйлап гастрольләрдә йөри; Россия һәм халыкара театр фестивальләрендә катнаша, берничә тапкыр ТР Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләге лауреаты («Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә — Д.Нуруллина, 2015; «Иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә — Р.Бариев, 2016; «Ел вакыйгасы» номинациясендә — «Хуҗа Насретдин» спектакле, Н.Исәнбәт әсәре буенча, 2015) була.

2015 тә театр труппасында — ТР һәм РФнең халык артистлары А.Гайнуллина, Н.Их-

санова, Р.Таҗетдинов, Ә.Шакиров, Р.Шәрәфиев; РФнең атказ. һәм ТРның халык артистлары И.Әхмәтҗанов, Н.Дунаев, Н.Гәрәева, Р.Мотыйгуллина, Д.Нуруллина, А.Хафизов, Илдар Хәйруллин, Р.Хәйретдинова; ТР һәм БРның халык артисты Г.Исәнгулова; ТРның халык артистлары Ф.Әкбәрова, И.Баһманов, И.Габдрахманов, А.Галиева, Х.Җәләлов, З.Зарипова, Н.Ибраһимова, Ф.Сафина, Р.Төхфәтуллин, Л.Хәмитова, Искәндәр Хәйруллин, Ә.Хисмәтов, Р.Юкачёва һ.б. Театрның баш режиссёры — ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе Ф.Р.Бикчәнтәев (2002 дән), баш рәссамы — ТРның халык рәссамы С.Г.Скоморохов, директоры — ТР һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре Ш.З.Закиров (1985 тән); И.И.Якупов (2012 дән).

*Әд.:* Татар совет театры. К., 1975; Иляловa И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала: Биогр. белешмәлек. К., 2005; шул ук. Театр имени Г.Камала. К., 1986; Арсланов М.Г. Татарское режиссёрское искусство (1906–1941). К., 1992; шул ук. Татарское режиссёрское искусство (1941–1956). К., 1996; шул ук. Татарское режиссёрское искусство (1957–1990). К., 2002; Игламов Н. Сотворение национальной сцены // Казань. 2007. № 4; Татарский государственный академический театр имени Галиаскара Камала: В 2 т. К., 2009.

*И.И.Илялова.*

**ТАТА́Р АКСУЫ́** (Кыр Аксуы) авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Буа–Яльчик автомобиль юлы буенда. 2010 елда 102 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, итккә терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 19 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык, балта эше, чабата үреп сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.А.нда 5 сәүдә-сәнәгать йорты була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 339,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Ырынгы волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1920 дә — 318, 1926 да — 270, 1949 да — 303, 1958 дә — 223, 1989 да — 119, 2002 дә — 116 кеше.

**ТАТА́Р А́ЛКИНЫ** посёлогы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 19 *км* көнбатыштарак, Чабаксар елгасы буенда. 2010 елда 10 кеше (татарлар) яши. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.А.нда мәчет (1911 ел тирәсендә төзелә; архит-ра истәлеге), вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 348 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Изгар волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 53, 1897 дә — 165, 1908 дә — 168, 1920 дә — 233, 1926 да — 250, 1938 дә — 216, 1949 да — 133, 1958 дә — 82, 1970 тә — 49, 1979 да — 41, 1989 да — 19, 2002 дә — 14 кеше.

**ТАТА́Р АРАДАШЛЫГЫ́** (Tatarische Mittelstelle, Tatarische Leitstelle), 1942–45 елларда Германиядә Оккупацияләнгән көнчыгыш өлкәләр министрлыгы (Көнчыгыш министрлыгы) каршындагы оешма. Башка арадашлыклар (Төркестан, Кырым татарлары һ.б.) б-н беррәттән Германиянең СССРдагы көнчыгыш халыклар б-н хезмәттәшлек итүен фаразлап большевизмга каршы көрәшү максаты б-н төзелгән була. Т.а.ның төп бурычы — «өченче рейх»та һәм оккупацияләнгән илләр терр-ясендә көнчыгыш халыклары вәкилләрен кайгырту һәм алар б-н җитәкчелек итү. Көнчыгыш министрлыгы каршында арадашлыкларның төп кураторы — проф. Г.*Менде*. Т.а. «Идел-Урал легионы»нда хезмәт итүчеләр составына, ш.у. *Төрки татарларның «Идел-Урал» көрәш берлегенә* (1945 елның гыйнварыннан) сәяси җитәкчелек итә. Т.а. составына 20–30 немец һәм татар керә, шулар арасында Ш.Алмас, Г.Солтан, Р.Самат, С.Кунафин була. Җитәкчеләре — адвокат Х.Унглаубе (1942–44), граф Л.Стамати (1944–45). 1945 нең язында, фашистлар Германиясе тар-мар ителгәннән соң, эшчәнлеге туктатыла.

*Әд.:* Гилязов И.А. Легион «Идель-Урал»: Представители народов Поволжья и Приуралья под знамёнами «третьего рейха». К., 2005.

*И.А.Гыйләҗев.*

**ТАТА́Р АТЛАРЫ́**, халык тарафыннан чыгарылган борынгы ат токымы. 12–13 йөзләрдән билгеле. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, 7–8 сәгать буе туктамый чабарга сәләтле, гаять чыдам атлар. Бияләр, башлыча, алтынсу ком төсендә, ял һәм койрыклары аксылрак. Айгырлар карасу алтын төстә, ял һәм койрыклары карарак, сырт буйлап кара тасма үтә. «Т.а.»н кытайлар үз язмаларында «күк атлары» дип атаганнар. Бүгенге көндә чиста токым хәлендә сакланып калмаганнар. Хәзерге вакытта Татарстан нәсел эше идарәсе һәм Казан вет. медицинасы академиясе галимнәре тарафыннан «Т.а.» токымын яңадан торгызу өстендә эш алып барыла. Татарстан районнарында, Башкортстан, Казакъстан респ-каларында, Чиләбе өлкәсендә үткәрелгән фәнни-экспедиция эзләнүләре нәтиҗәсендә «Т.а.»на охшаш атларның исәбе билгеләнә. Хәзерге вакытта андый атлар Лениногорск районында — Ф.Нәбиуллин шәхси хуҗалыгында тупланган. Баш саны 53 бия һәм 2 айгыр. Эзләнүләр һәм аларны бер урынга туплап ат көтүе хәленә китерү эше дәвам итә. Бу атларны чиста хәлдә үрчетеп, Россия дәүләт комиссиясе алдында «Т.а.» итеп раслау планда каралган.

*Әд.:* Мулладжанов Н. Татар атка менсә // Ватаным Татарстан, 2010. № 10; Книга о лошади. М., 1969. Т. 3; Мулладжанов Н. Татарские кони // Звезда Поволжья, 2010. № 38.

*Р.Ә.Хәертдинов.*

**ТАТА́Р ӘДӘБИЯТЫ́**. 6–12 йөзләр гомумтөрки мәдәни язма ядкәрләргә һәм фольклор мирасына барып тоташа. Борынгы төрки текстлар, рун язмалы кабер ташлары, *Мәхмүд Кашгариның* «Диване лөгать әт-төрк» җыентыгы, *Й.Баласагуниның* «Котадгу белек» поэмасы, 12 йөз шагыйрьләре *Ә.Йүгнәки*, *Ә.Ясәви*, *С.Бакыргани* әсәрләре Т.ә.ның тамырларын тәшкил итәләр. Беренче сүз сәнгате үрнәкләренә синкретизм, фольклорга һәм мифологиягә якынлык, дин б-н тыгыз элемтә, тематика һәм жанр төрлелеге хас.

Төрки-татар сүз сәнгатенең алдагы язмышы органик рәвештә ислам һәм Шәрекъ, беренче чиратта, гарәп-фарсы һәм төрки әдәбиятлары б-н бәйле. Шәрекъ әдәбиятының классик әсәрләре, аерым алганда, *әл-Мәгарри, әл-Газали*, әбу Хәмид, *Фирдәүси, Низами Ганҗәви, Гаттар, Сәгъди, Руми, Нәваи* әсәрләре, ш.у. «*Кәлилә вә Димнә*», «*Мең дә бер кичә*», «*Тутыйнамә*», «*Мөхәммәдия*» һ.б. әсәрләр оригинал, тәрҗемә, назыйрә формасында укылганнар, яңа әсәрләр язылыр өчен илһам чыганагы да булып торганнар. *Гаруз* гарәп метрик системасы, Шәрекъ әдәбиятының аерым жанрлары һәм поэтик формалары, сәнгатьчә матурлык тудыру чаралары татар сүз сәнгатендә зур урын алып тора. Шәрекъ әдәбиятларының эстетик тәҗрибәсен үзләштерүдә мөһим этап — болгар-татар шагыйре *Кол Галинең* «Кыйсса-и Йосыф» (13 йөз башы) поэмасы. Әсәрдә халыкның «камил инсан» һәм гадел хөкемдар турындагы хыялы сәнгатьчә гәүдәләнә. Кол Гали поэмасы гасырлар дәвамында татар һәм төрки телле халыкларның яраткан китабы булып кала.

Алтын Урда чорында (13–15 йөзләр) төрки-татар әдәбияты күтәрелеш кичерә. *Газәл, касыйдә, мәдхия, мәрсия, робагый, фәрд*, шигъри роман, *хикәйәт, кыйсса, дастан, повесть, кысалы кыйсса* һ.б. жанрлар актив үсеш ала. *Рабгузинең «Кыйссас әл-әнбия», Котбның* «Хөсрәү вә Ширин», Харәзминең «Мәхәббәтнамә», *Мәхмүд Болгариның* «Нәһҗел-фәрадис», *Хисам Кятибнең* «Җөмҗөмә солтан», *Сәйф Сараиның* «Китабе Гөлестан бит-төрки», «Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәрләре, *Әхмәд Хуҗа әс-Сараи, Мәүла Казый Мөхсин* һ.б. авторларның лирик шигырьләре идея-тематик байлыгы, гуманистик эчтәлеге, шигъри камиллеге, теленең һәм стиленең нәфислеге б-н аерылып тора. Билгесез авторның фольклорга һәм мифологиягә нигезләнгән, сюжеты мөселман идеологиясе б-н сугарылган «*Кисекбаш китабы*» (14–15 йөзләр) популяр поэтик әсәрләрнең берсен тәшкил итә. Соңыннан Г.*Тукай*, аңа «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» исемле нәзыйрә язып, бу билгеле сюжетка үз заманы өчен яңа сатирик эчтәлек бирә. 15 йөз уртасында язма һәм чәчмә әдәбиятлар синтезы нигезендә төрки-татар халкының катлаулы һәм фаҗигале тарих сәхифәләрен чагылдыручы «*Идегәй*» дастаны иҗат ителә. Алтын Урданың матди һәм рухи казанышларын мирас итеп алган Казан, Әстерхан, Себер ханлыкларында, Нугай Урдасында *Өмми Камал, Хәсән Кайгы, Мөхәммәдәмин* әл-Болгари, *Колшәриф* һ.б. язучылар иҗат итәләр. *Мөхәммәдъярның* «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» поэмаларында гуманизмга, игелекле гамәлләргә дан җырлана. Поэмада авторның ватан язмышы өчен борчылуы сизелә. Колшәрифнең «Зафәрнамәи вилаяти Казан» әсәрендә камап алынган Казан халкының Мәскәүнең басып алуына каршы батырларча көрәше, Казан-

ның матурлыгы күрсәтелә, аның татар халкы һәм дәүләте өчен әһәмияте раслана.

16 йөз уртасында Идел буе татарлары бәйсезлекләрен югалталар, христианлаштыру һәм руслаштыруга дучар ителәләр, болар исә татар әдәбияты үсешенә гаять тискәре йогынты ясый. Кыйммәтле язма ядкәрләр юк ителә, халыкның иҗади көченә зыян килә. Шуңа карамастан, татар сүз сәнгате яши, яңа әсәрләр (күп булмаса да) туа.

17 йөзнең 2 нче яртысы шагыйре *Мәүла Колый* хикмәтләрендә, аның кече замандашы *Габди* әсәрләрендә заманның мөһим иҗтимагый һәм әхлакый мәсьәләләре чагыла. *Габдессәлам бине Ураи* шигырьләрендә хис-тойгылар муллыгы, фольклор әсәрләренә, аеруча халык җырларына якынлык күзәтелә.

18 йөзнең соңгы чиреге — 19 йөз татар әдәбиятына урта гасырлар романтизмы традицияләрен дәвам итү хас. *Утыз Имәни, Гали Чокрый, Акмулла* шигырь һәм поэмаларында белем, акыл, кешелеклелеккә дан җырлана, әхлакый камил шәхес образын тудыруга омтылыш сизелә. Ә.*Каргалый*, Һ.*Салихов*, Ш.*Зәки* сәнгатьчә чагылдыру юлында урта гасырлар дини-суфичылык әдәбияты традицияләрен дәвам итәләр. Т.*Ялчыголның* «Рисаләи Газизә» әсәре берничә буын укучыга дини-әхлакый тәрбия бирә. 19 йөз татар поэзиясе үсешендә яңа сәхифәне Г.*Кандалый* иҗаты ачып җибәрә. Аның халык җырларына тартым әчкерсез лирикасы, мәхәббәт турындагы романтик поэмалары дөньяви әдәбият тудыруда зур әһәмияткә ия. Язучы-энциклопедистлар К.*Насыйри*, Р.*Фәхретдин* татар мәгърифәтчелек әдәбияты формалашуга зур өлеш кертәләр. Ә.*Кормашиның* традицион сюжетларга нигезләнеп язылган «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә», «Кыйссаи бүз егет» мәхәббәт поэмалары татар халкында гына түгел, башка төрки халыкларда да популяр була. 18–19 йөзләр татар әдәбиятында эпосның *сәяхәтнамә*, повесть кебек жанрлары активлаша. 19 йөзнең соңгы чирегендә Г.*Ильяси*, Ф.*Халиди* драмалары иҗат ителә. Француз, рус, төрек детектив әдәбияты традицияләрен иҗади үзләштереп, З.*Бигиев* танылган «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» һәм «Гөнаһе кәбаир» романнарын яза. Ф.*Кәрими*, Ш.*Мөхәммәдов*, З.*Һади* реалистик хикәя һәм повестьлар иҗат итәләр. Аларда шул вакыттагы татар тормышыннан алынган төрле характерлар һәм типлар сурәтләнә. 19 йөзнең 2 нче яртысында, аеруча 20 йөз башында татар сүз сәнгатенә рус, Көнбатыш Европа әдәбиятларының йогынтысы арта.

Шәрекъ һәм Гареб цивилизацияләренең мәгърифәтчел казанышларын үзләштерү нәтиҗәсендә 19 йөзнең 2 нче яртысыннан сәнгатьчә фикерләү үсешендә катлаулы үзгәрешләр башлана. Ул, үз чиратында, татар әдәбияты тарихында «алтын чор» дип аталган 20 йөз Яңарыш әдәбиятының нигезен хасил итә.

20 йөз башында кискен иҗтимагый тетрәнүләр киң халык массаларын хәрәкәткә китерә, аларны милли мәнфәгатьләр, демократия һәм шәхесне изелүдән коткару өчен көрәшкә җәлеп итә. Санаулы еллар эчендә татарча китап басу, вакытлы матбугат бастыру, белем-мәгърифәт, театр, фән моңа кадәр күрелмәгән югарылыкка күтәрелә, Казан, Уфа, Оренбург, Әстерхан, Самара, Мәскәү, Петербург, Җаек, Ташкент һ.б. шәһәрләрдә үсеш ала. Т.ә., үзенең күпгасырлык казанышларына таянып, Шәрекъ һәм Гаребнең сәнгати-эстетик тәҗрибәсен иҗади файдаланып, мәгърифәтчелек реализмыннан тәнкыйди реализмга һәм романтизмга таба үсеш кичерә. 20 йөз башында Т.ә. даһи Г.Тукай Г.*Исхакый*, Г.*Ибраһимов*, Ф.*Әмирхан*, *Дәрдемәнд*, Г.*Камал* һ.б. сүз осталарының талантлары б-н балкып, татар халкының мөһим ихтыяҗларына җавап бирүдә, рухи тормышын агартуда зур уңышларга ирешә. Реалистик юнәлеш Тукай поэзиясен, Г.Исхакыйның проза һәм драматургиясен, аеруча милләт язмышы өчен кайгыру б-н сугарылган «Ике йөз елдан соң инкыйраз» ярымпублицистик әсәрен, Г.Камалның комедияләр һәм драмаларын, Ф.Әмирхан, Ш.*Камал* иҗатларын колачлый. Романтизм Г.Ибраһимовның хикәяләре һәм «Яшь йөрәкләр» романында, М.*Фәйзи* драматургиясендә, С.*Рәмиевнең* гыйсъянчылык лирикасында, Н.*Думави* һәм Ш.*Бабич* иҗатларында аваз сала. 20 йөз башы Т.ә. идея-тематик байлыгы, жанр һәм стиль үзенчәлеге, поэтик сөйләм камиллеге б-н аерылып тора. Реализм һәм романтизм б-н беррәттән, бу чор Т.ә.нда модернистик сәнгать чалымнары күзәтелә башлый, аерым алганда, Дәрдемәнднең сагышлы лирикасында, Ш.Камал, Г.*Гобәйдуллин* хикәяләрендә һ.б.да символизм күренешләре пәйда була. Иҗади эзләнүләрнең төрлелегенә карамастан, авторларны татар халкының киләчәге, туган тел язмышы, милли үзенчәлекләрне саклап калу турындагы уйланулар берләштерә.

Окт. рев-циясеннән Т.ә.нең социаль яңгырашы һәм тематик-фәлсәфи юнәлеше кискен үзгәрә. Социаль тетрәнүләр халык массаларында иҗади энергия уята, һәм 1920 еллардагы мәдәни күтәрелеш, Т.ә. «алтын чоры»ның традицияләрен үзгәртеп, яңа тенденцияләр барлыкка китерә. Нәтиҗәдә, катлаулы күренеш пәйда була: совет әдәбияты туа. Яңа идеалларга дан җырларга, элеккеләрен фаш итәргә әзер булган язучылар буыны үсеп җитә. Ләкин чынбарлыкны объектив аңларга тырышкан кешеләр дә була, ә кайберләре, мәс., Г.Исхакый, чит илгә китә. Язучыларның төп өлеше, ш.и. Г.Ибраһимов, К.*Тинчурин*, Ф.*Бурнаш*, Ш.*Усманов* (Сталин репрессияләре елларында гомерләре фаҗигале рәвештә өзелә), М.*Гафури*, Ш.Камал, Г.Камал һ.б. яңа хакимият б-н хезмәттәшлек итә башлый. Дәрдемәнд, Ф.Әмирхан, С.Рәмиев, С.*Сүнчәләй*, Н.Думави, пролетариат диктатурасына карата протест белдереп, иҗтимагый-иҗади эшчәнлектән читләшәләр.

Татар совет әдәбиятында яңа исемнәр пәйда була: Һ.*Такташ*, Х.*Туфан* (аларның 1920 елларга караган иҗатларында поэма жанры аеруча күтәрелә), М.*Җәлил*, С.*Баттал*, Ш.*Маннур* һ.б. Драматургия күтәрелеш кичерә, тематик һәм жанр формалары ягыннан тармаклана: бу Һ.Такташның «Җир уллары трагедиясе»ннән башланып, К.Тинчурин, Н.*Исәнбәт*, Т.*Гыйззәт*, соңыннан Х.*Вахит*, А.*Гыйләҗевнең* иҗади эзләнүләрендә дәвам итә. Язучыларның күбесе үз иҗатларында идеология чикләреннән арынырга, халык тормышының тирәнтен төпкелләрен өйрәнергә омтылып, соц. реализм кысаларыннан читкә чыгалар, аларның әсәрләре сәнгати чараларның күптөрлелеге б-н аерылап тора. Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар», М.*Галәүнең* «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» романнары, Г.*Кутуйның* «Тапшырылмаган хатлар», Г.*Бәшировның* «Сиваш», Ф.*Хөснинең* «Йөзек кашы» повестьлары, М.Җәлилнең «Алтынчәч», «Хат ташучы», Ф.*Кәримнең* «Тавышлы таң», Ә.Фәйзинең «Флейталар» поэмалары милли әдәбиятның матур сәхифәләрен тәшкил итә. 1941–45 еллар Т.ә. халыкның сугыш елларында кичергән уй-хисләренең барлык төсмерләрен чагылдыра; бу күренеш татар халкы турында бөтен дөньяга хәбәр салган М.Җәлилнең «Моабит дәфтәре»ндә, Ф.Кәримнең романтик-патриотик поэзиясендә, Н.*Баян*, Н.*Арсланов*, Ш.*Мөдәррис* иҗатында, Г.*Әпсәләмов*, И.*Гази* һ.б. прозасында чагылыш таба.

Сугыш елларындагы күтәрелештән соң Т.ә. сугыштан соңгы тыныч еллар авырлыкларына әзерлексез була; кискен социаль мәсьәләләрдән читкә алып китүче, тормышны берьяклы, артык оптимистик төстә тасвирлаучы әсәрләр языла. «Җепшеклек» (1960 еллар) чорына демократик үзгәрешләргә, милли яңарышка, дәүләтнең изүеннән котылуга, шәхес ирегенә өметләнү хас була. «Онытылган» күп кенә исемнәр кире кайта: Х.Туфан, Ф.Бурнаш, К.Тинчурин, М.Галәү һ.б. Г.Бәширов, Ф.Хөсни, Ә.*Еники*, М.*Әмир*, А.*Расих*, Г.*Ахунов*, М.*Юныс* прозасында, Х.Туфан, С.*Хәким*, Н.Арсланов, Г.*Афзал*, С.*Сөләйманова*, Ә.*Баян*, Ш.*Галиев*, Роберт *Әхмәтҗанов* поэзиясендә, Р.Ишморат, Т.*Миңнуллин*, Ш.Хөсәенов, И.*Юзиев*, Р.*Мингалим*, Р.*Хәмид*, Ю.*Сафиуллин*, Д.*Салихов* драматургиясендә милли характер, рухи дөнья б-н кызыксыну арта. Демократик үзгәрешләр дулкынында поэзиягә Ә.*Рәшит*, Ф.*Яруллин*, Рәшит *Әхмәтҗанов*, Р.*Харис*, Р.*Гатауллин*, К.*Сибгатуллин*, Р.*Фәйзуллин*, Л.*Шагыйрьҗан*, Х.*Җюпов*, М.*Әгъләмов*, Н.*Әхмәдиев*, *Зөлфәт*, З.*Мансуров*, Р.*Низамиев* һ.б. килеп кушылалар. 1970–80 елларда экологик, социаль үзгәрешләргә, авыл кешесе язмышы, авылның социаль-әхлакый проблемаларына җавап рәвешендә, «авыл прозасы» формалаша (Р.*Төхфәтуллин*, М.*Мәһдиев*, *Хәсән Сарьян*, Б.*Камалов*, В.*Нуруллин*, Ф.*Садриев*).

Үзгәртеп кору чорында (1990 еллар) беренче планга татар халкы тормышының хәлиткеч мизгелләрен, аның дәүләтчелеге мәсьәләләрен чагылдырган тарихи романнар чыга (Н.*Фәттахның* «Сызгыра торган уклар», М.*Хәбибуллинның* «Кубрат хан», Р.*Батулла*, Ф.*Латыйфи*, С.*Шәмси*, В.*Имамов* романнары). Сугыш темасы тагын да дөресрәк һәм тирәнрәк итеп яктыртыла башлый (Х.*Камалов*, М.*Юныс*). 1980–90 елларда Т.ә.нда ГУЛАГ, Сталин лагерьлары (И.*Салаховның* «Колыма хикәяләре», А.*Гыйләҗевнең* «Йәгез, бер дога!», Г.*Тавлинның* «Афәт», Р.*Кәраминең* «Каргышлы этаплар» романнары) темалары актив

яктыртыла. Реализм һәм романтизм чикләренең киңәюе, кеше акылының мөмкинлекләрен ачу өчен модернизм алымнарына мөрәҗәгать итү Т.ә.ның поэтикасын баета. Г.*Гыйльмановның* «Албастылар», М.*Гыйләҗевнең* «Бичура», Н.*Гыйматдинованың* «Ак торна каргышы», Ф.*Бәйрәмованың* «Болын» әсәрләре — шундыйлардан. 1980 еллар ахырында — 1990 еллар башында әдәбият татар милләтен торгызу, аның дәүләтчелеген кайтару, мәдәниятен, телен саклап калу өчен көрәш мәйданына әйләнә. Халыкның үткәнен, бүгенгесен әхлакый-фәлсәфи бәяләүче, аның киләчәге өчен тирәнтен кайгыручы язучылар барлыкка килә; реализм милли төсмер ала (А.*Хәлим*, Ә.*Гадел*, Ф.Бәйрәмова, Рәшит Әхмәтҗанов, Г.*Морат*, З.*Хәким*, З.*Хөснияр*, Р.*Зәйдулла*). 20 йөз ахырында әдәбиятка яшь язучылар килә: Сөләйман, Р.Әймәт, Л.*Янсуар*, М.Закир һ.б. Аларның иҗади эзләнүләре татар әдәбиятының киләчәген оптимистик рухта бәяләргә мөмкинлек бирә. Ш.у.к. *Татар драматургиясе, Татар поэзиясе, Татар прозасы.*

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. К., 1984–2001; К., 2003; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек: 2 томда. К., 2009.; История татарской советской литературы. М., 1965; Гайнуллин М.Х. Татарская литература и публицистика начала XX в. К., 1966; Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Библиогр. справочник. К., 1970; Гайнуллин М. Татарская литература XIX в. К., 1975; Галиуллин Т. Здравствуй, поэзия. Очерки о современной татарской поэзии. М., 1987; Миннегулов Х. Татарская литература и Восточная классика. К., 1993; Средневековая татарская литература VIII–XVIII вв. К., 1999; История татарской литературы нового времени. К., 2003.

*Х.Й.Миңнегулов, Т.Н.Галиуллин.*

**ТАТА́Р ӘДӘБИЯТЫ́ ҺӘМ СӘНГАТЕ́ ДЕКА́ДАСЫ МӘСКӘҮДӘ́**, к. *Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы.*

**ТАТА́Р ӘҖИЛЕ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 43 *км* көньяк-көнбатыштарак, Гөбенә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 73 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1567 дән рус чыганакларында Азилеева авылы буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1907 дә төзелә), мәдрәсә, 3 ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 429 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 52 ир-ат; 1859 да — 174, 1897 дә — 385, 1908 дә — 465, 1920 дә — 422, 1926 да — 394, 1938 дә — 290, 1949 да — 393, 1958 дә — 321, 1970 тә — 224, 1979 да — 161, 1989 да — 122, 2002 дә — 94 кеше.

**ТАТА́Р ӘЙШӘСЕ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 30 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 161 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Клуб, китапханә. Казан ханлыгы чорыннан билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, умартачылык, бау ишү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Ә.ндә мәчет, мәктәп, су тегермәне, 2 вак-төякләр һәм 2 тукыма кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 554,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 75 ир-ат; 1859 да — 392, 1897 дә — 696, 1908 дә — 756, 1920 дә — 683, 1926 да — 773, 1938 дә — 671, 1949 да — 592, 1958 дә — 473, 1970 тә — 375, 1989 да — 197, 2002 дә — 189 кеше. Т.Ә. зиратында 16 йөзнең 1 нче яртысы эпиграфик истәлеге — кабер ташы саклана.

**ТАТА́Р ӘХМӘТЕ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 25 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 402 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1692 дән Әхмәт авылы буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Ә.ндә 2 мәчет, мәдрәсә, 3 тегермән, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1596,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Юхмачы волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 221 ир-ат; 1859 да — 761, 1897 дә — 1002, 1908 дә — 1328, 1920 дә — 1411, 1926 да — 650, 1938 дә — 599, 1949 да — 453, 1958 дә — 513, 1970 тә — 788, 1979 да — 623, 1989 да — 445, 2002 дә — 468 кеше.

**ТАТА́Р ӘХМӘТЕ́ ТО́РФЛЫ САЗЛЫГЫ́**, ландшафтлы табигать истәлеге. Әлки р-ны терр-ясендә, Татар Әхмәте авылыннан көньяктарак урнашкан. 1985 елда билгеләнә. Мәйданы 15 *га*. Сулы-сазлыклы комплекс (3 *га* гаякын мәйданда күл, 5 *га* да сазлык массивы), Кече Чирмешән елгасының 1 нче тугай өсте террасасындагы катнаш урман (каен, нарат) әйләндереп алган. Үләнчел үсемлекләрнең 50 дән артык төре, ш.и. ТРның Кызыл китабына кертелгән: кәрлә каен (ареалның көньяк чиге), розмарин яфраклы тал, киң яфраклы мамыкбаш, яшел чәчәкле каешъяфрак, сазлык йод үләне, саз билчәне, скипетрсыман тубалак үсә. Торфның көллелеге 35% ка кадәр; pH — 5,2–6,6, CaO — 0,7–12,8, $P_2O_5$ — 0,05–0,56, $Fe_2O_3$ — 0,6–15,7 (коры массага карата % ларда).



Татар Әхмәте торфлы сазлыгы.

**ТАТА́Р ӘХТИЯЛЫ́** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 23 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 99 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1680 нән Әхтиял елгасы буендагы Пүчинкә исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре һәм асабалар катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1879 елгы мәгълүматларга караганда, су тегермәне, 1887 дә мәктәп эшли. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 480,3 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1802 дә — 34 ир-ат; 1836 да — 146, 1859 да — 177, 1870 тә — 190, 1887 дә — 244, 1905 тә — 333, 1911 дә — 370, 1920 дә — 402, 1926 да — 279, 1938 дә — 498, 1949 да — 412, 1958 дә — 369, 1970 тә — 315, 1979 да — 248, 1989 да — 162, 2002 дә — 158 кеше.

**ТАТА́Р БАГАНАЛЫСЫ́** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 27 *км* көньяктарак, Чистай–Нурлат автомобиль юлы буенда. 2010 елда 608 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чоры авылы урынында 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Вершина речки Боганы исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәдрәсә, 4 тегермән, 2 ярма яргыч, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2036 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Мөслим волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 167 ир-ат; 1859 да — 905, 1897 дә — 1391, 1908 дә — 1631, 1920 дә — 1788, 1926 да — 1504, 1938 дә — 1554, 1949 да — 1135, 1958 дә — 934, 1970 тә — 1177, 1979 да — 1070, 1989 да — 779, 2002 дә — 690 кеше.

**ТАТА́Р БАСМА́ КИТАБЫ́**, татар телендәге иң беренче басма текст булып Пётр I нең Прут походы уңаеннан чыгарган 1711 ел Ма-

нифестының рус теленнән татарчага тәрҗемәсе тора; гарәп алфавитындагы әлеге текст хәреф җыеп түгел, ә уемлап язылган калыптан басылган була. Татар телендәге беренче хәреф җыеп басылган язма — Иранга яу турындагы Манифест — 1722 дә Пётр I нең Поход (йөзмә) басмаханәсендә дөнья күрә. 18 йөзнең соңгы чирегендә татар телендә берничә закон акты, ш.и. «Россия империясендәге губерналарны идарә итү учреждениеләре» («Учреждения для управления губерний Российской империи») һәм «Җәмәгать тәртибен саклау Идарәсе кагыйдәләре» («Положение Управы Благочиния», 1798 дә И.С.Хәлфин тарафыннан тәрҗемә ителә) чыга. 18 йөзнең 2 яртысында шәрекъ телләрен дипломатия һәм миссионерлык максатларында өйрәнү зарурлыгы уку китаплары: С.Хәлфиннең «Татар теле әлифбасы»н (М., 1778) әзерләүне шарт итеп куя. 1780 елларда гарәп шрифтында җыелган китаплар сирәк кенә Петербургта (ФА һәм И.Шнор басмаханәләрендә) басыла, 1785 тә бирedә *Азия басмаханәсе* ачыла, анда 1787 дә Екатерина II Фәрманы б-н беренче тапкыр Коръән нәшер ителә (1790 елларда күп тапкырлар кабатлап бастырыла). Төрки-татарлар арасында мөселман Шәрегының китап мәдәнияте Идел буе Болгар дәүләте чорында ук киң таралыш ала, тик Казан ханлыгы җимерелү сәбәпле, үз басмалары 19 йөз башында гына барлыкка килә. Татар китабы үсеше Казанда 1800 елда *Азия басмаханәсе* (Гимназия басмаханәсе) ачылу б-н бәйле. 1801 дә анда «Әттәхият» һәм «Һәфтияк» (Коръән сүрәләре һәм өземтәләре җыентыгы; нашире — басмаханәне беренче булып арендага алучы Г.*Бурашев*) уку китаплары, 1802 дә — 7 исемдәге китап («Әлифба иман шартлары белән»; «Пиргули васыйәте», «Устувани китабы» һ.б.) басыла. 1829 да Азия басмаханәсе Казан ун-ты басмаханәсе б-н берләштерелә (соңрак татар китаплары нәшер итү үзәгенә әверелә).

1840 еллар башында татар китаплары Казанның шәхси басмаханәләрендә (*Л.В.Шевиц басмаханәсе, Р.Сәгыйтов басмаханәсе, Ш.Яхин басмаханәсе*) чыгарыла башлый, тик цензура тыюлары аркасында аларның эшчәнлеге туктатыла; татар китаплары 1849 дан алып ун-т басмаханәсе һәм *Н.П.Коковин басмаханәсе* тарафыннан кабат бастырыла башлый. 1840–70 елларда иң актив наширләрнең берсе мәгърифәтче һәм тәрҗемәче Рәхмәтулла *Әмирханов* була. Китаплар чагыштырмача зур тираж б-н (2400 данәдән дә ким түгел, нигездә, 3300 яки 4200 данә, кайвакыт — 6300 данәгә кадәр), гади бизәлештә, йомшак кәгазь тышлыкта, 1830 дан титул бите б-н чыгарыла. Басмаларны ислам кагыйдәләре җыелмасы, борынгы татар һәм шәрекъ әдәбияты һәм фольклоры ядкәрләре, тарихи хезмәтләр, мөселман хокукы буенча җыентыклар, дәреслекләр, рус уку йортлары өчен татар теле грамматикалары һәм сүзлекләре, медицинага караган хезмәтләрнең тәрҗемәләре һ.б. тәшкил итә. 1801–50 дә Казанда 401 татар китабы чыга. Бу чорда Россия провинцияләрендә нәшер ителгән һәр өченче китап (1463 исемдә) татар телендә була. 19 йөзнең 1 яртысында татар телендәге китаплар сирәк кенә С.-Петербургта, Мәскәүдә, ш.у. Оренбург һәм Әстерхан шәһәрләрендә бастырыла.

1850 еллардан башлап татар телендә дөньяви әсәрләр (дәреслекләр, сүзлекләр һәм Г.*Ваһапов*, С.*Кукляшев*, М.*Бикчурин* һ.б.ның хрестоматияләре) нәшер ителә башлый. Алга таба мондый басмаларның тоткан урыны геогр., тарих, филол., пед. буенча дәреслекләр, фәнни-популяр һәм белешмә китаплар (Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Мәхмүдов, Г.Фәезханов, Г.Ильяси, Ш.Таһиров, Т.Яхин һ.б. хезмәтләре) хисабына арта; яңа, реалистик татар әдәби әсәрләре (З.Бигиев, М.Акъегетзадә, Ф.Халиди һ.б.) басыла. Сериялэп нәшер ителүче басмалар, балалар китаплары, календарьларның яңа төрләре барлыкка килә, зур күләмдә дини әдәбият чыгарыла. Китапларның күп өлеше Казанда, рус һәм татар басмаханәләрендә (ун-т, Н.П.Коковин, И.Н.Харитонов, К.А.Тилли, Г.М.Вечеслав, Б.Л.Домбровский, И.С.Перов, И.А. һәм А.А.Абдуллиннар, бертуган Кәримовлар һ.б.) нәшер ителә.

19 йөзнең 2 яртысында Россиядә татар телендә гомуми тиражы 26854000 данә булган 3242 китап басыла (уртача алганда, һәр китапның күләме 6 басма табак була, тиражы — 7600 данә). Аларның 3162 се — Казанда, 80 китап башка шәһәрләрдә (Петербург, Мәскәү, Оренбург, Уфа) басыла.

20 йөз башында татар китапларын нәшер итү һәм тарату б-н китап ширкәтләре (бертуган Кәримовлар, «*Сабах», «Мәгариф», «Гасыр*» һ.б.) шөгыльләнә башлый, алар б-н беррәттән Казан, Оренбург, Петербург, Уфа, Эстәрлетамак, Троицк, Әстерхан һ.б. шәһәрләрдә аерым татар нәшриятлары һәм басмаханәләре («*Тормыш», «Иршад*», «*Акча*» һ.б.) эшли. Басмалар саны буенча татар китабы — бары рус һәм латыш китапларыннан, тираж буенча рус телендәге китаплардан гына калыша. 20 йөз басмалары арасында төп урынны дәреслекләр, үгет-нәсыйхәт һәм дидактика характерындагы китаплар, татар матур әдәбияты әсәрләре, белешмәлекләр алып тора. Әдәби альманах һәм җыентыклар, әсәрләр тупланмалары, геогр. карта альбомнары, серияле яңа басмалар («Мәктәп китапханәсе», «Балалар китапханәсе», «Театр китапханәсе», «Фән һәм техника» һ.б.) барлыкка килә. Халык җырлары, әкиятләре, табышмаклары җыентыклары, классик шәрекъ әдәбияты әсәрләре, тарих, фәлсәфә буенча китаплар басыла. Дини әдәбият элеккечә зур тиражлар б-н (100000 данәгә кадәр) нәшер ителә.

20 йөз башында татар китапларының полиграфик эшләнешендә һәм бизәлешендә зур үзгәрешләр барлыкка килә, яңа рәсемнәр һәм шрифт кегльләре, бизәкләр кулланыла башлый, рәсемле басмаларга зур игътибар бирелә. 1910 еллар башыннан иллюстрацияләр берничә төсле буяу б-н басыла башлый.

*Әд.:* Китапка хитап — Слово о книге. К., 1994; Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; шул ук. Татарская книга пореформенной России. К., 1983; шул ук. У истоков татарской книги. К., 1992; Габдельганеева Г.Г. Полиграфия и печать в Казанской губернии. 1800–1917 гг. К., 2005.

*Г.Г.Габделганиева.*

**ТАТА́Р БИДӘҢГЕСЕ́** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 43 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бидәңге елгасы буенда. 2010 елда 371 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1696 га кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Бидәңге исеме б-н дә билгеле. 1720 еллардан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–1860 елларда халкының бер өлеше Удел ведомствосы буйсынуында була; игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу һәм чүлмәк ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәктәп, 5 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1339,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Сембер өязе Сөендек волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 809, 1897 дә — 1289, 1913 тә — 1576, 1920 дә — 1483, 1926 да — 1430, 1938 дә — 1390, 1949 да — 1092, 1958 дә — 959, 1970 тә — 878, 1979 да — 699, 1989 да — 483, 2002 дә — 419 кеше.

**ТАТА́Р БИЗНӘСЕ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 10 *км* көнбатыштарак, Бизнә елгасы (Суранын уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 462 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, иткә терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1665–67 еллардан Мемкеева буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашманлык йөкләмәсен үти; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 3 мәчет, 3 мәдрәсә, 22 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2720,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Чүпрәле волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 1195, 1897 дә — 1993, 1913 тә — 2741, 1920 дә — 2398, 1926 да — 2123, 1938 дә — 1820, 1949 да — 1233, 1958 дә — 812, 1970 тә — 776, 1979 да — 752, 1989 да — 472, 2002 дә — 495 кеше.

**ТАТА́Р БИМОРЗАСЫ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 18 *км* көньяктарак, Казан–Ульянов автомобиль юлы буенда. 2010 елда 77 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 17 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Биморза буларак та телгә алына. 1720 елларда халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–1860 елларда Удел ведомствосы буйсынуында; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 1 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 358,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959

ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1913 тә — 175, 1920 дә — 214, 1926 да — 201, 1938 дә — 275, 1958 дә — 186, 1970 тә — 203, 1979 да — 149, 1989 да — 115, 2002 дә — 90 кеше.

**ТАТА́Р БИСТӘЛӘРЕ́**, Казанда татарларның таралып яши торган урыны. 1552 елда Казан ханлыгын Рус дәүләте яулап алганнан соң барлыкка килә. Иң билгелесе — 18 йөз уртасына кадәр Түбән Кабанның сулъяк ярында һәм Болак тамагында урнашкан *Иске Татар бистәсе*. 18 йөзнең 2 нче яртысына кадәр андагы төзелеш стихияле була. Шәһәрнең даими планы расланганнан соң (1768), Казан төгәл рәвештә шәһәргә һәм бистә-шәһәр яны җирләренә бүленә. Евангелистлар урамы (хәзерге Татарстан урамы) Иске Татар бистәсен ике өлешкә бүлә. Бистәнең төньяк-көнбатыш ягы, Болак арты өлеше проект буенча шәһәр чигенә туры килә һәм яңа план буенча үзгәртеп төзелә. Регуляр планга кадәр төзелгән Иске Татар бистәсенең төп өлеше шәһәр читендә кала. Шул вакытлардан алып совет чорының адм. үзгәртеп коруларына кадәр бистәнең исеме рәсми рәвештә план буенча Кабан күленең көньяк-көнбатыш яр буе терр-ясенә карата гына кулланыла. Берсе рәсми — Кабан артында, икенчесе — элеккегесе, татар халкы сөйләмендә урнашып калганы, әлеге рәсми өлештән тыш *Печән базары* б-н янәшә урнашкан Болак арты кварталларын да үз эченә ала.

18 йөз уртасында Иске Татар бистәсендә яшәүче халыкның бер өлеше күчерелү нәтиҗәсендә шәһәрнең көньяк-көнбатыштагы үзән җирендә *Яңа Татар бистәсе* барлыкка килә, анда 5 мәчет, ш.и. *Әҗем мәчете* һәм *Иске Таш мәчет* эшли. 20 йөз башында ике бистә *Казаковлар мәчете* урнашкан җирдә кушыла. Шәһәрнең татар халкы яшәгән көнчыгыш чиге — Болак елгасының сулъяк яры һәм Түбән Кабан буеннан, төньягы хәзерге Үзәк базар һәм Г.Камал урамнары тирәсеннән узган. Шәһәрнең татар халкы яшәгән төбәгенең үзәк өлеше Печән базары һәм *Печән базары мәчете* урнашкан мәйдан булган.

Казан артындагы зур булмаган бистәләр *Бишбалта бистәсе* (2 мәчет), *Дары заводы бистәсе* (2 мәчет), *Ягодный бистәсе* (1 мәчет) составында формалаша. Совет чорында элеккеге Т.б. торак районнардагы яңа төзелешләр б-н кушылып бетә.

*Әд.:* Старо-Татарская слобода — от прошлого к будущему: Материалы науч.-практ. конф. К., 2001; Татарские слободы Казани: Очерки истории. К., 2002. *Х.Г.Надыйрова.*

**ТАТА́Р БОРНАЕ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 32 *км* көньяктарак, Борнай елгасы буенда. 2010 елда 401 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 16–17 йөзләргә кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Б.нда мәчет, мәдрәсә, 3 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1572,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Кузнечиха волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 119 ир-ат; 1859 да — 702, 1897 дә — 968, 1908 дә — 1100, 1920 дә — 1221, 1926 да — 596, 1938 дә — 601, 1949 да — 622, 1958 дә — 692, 1970 тә — 811, 1979 да — 669, 1989 да — 532, 2002 дә — 468 кеше.

**ТАТА́Р БОРНАШЫ́** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 28 *км* көнбатыштарак, Зөя елгасыннан 1,5 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 492 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1647–52 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Архангельское буларак билгеле. 1860 елларга кадәр халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, штукатурлау һәм йон тетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Б.нда Михаил-Архангел чиркәве (1878 дә төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе (1884 дә ачыла), 5 җил тегермәне, 3 май язу з-ды, йон тетү йорты, 1 казна шәраб һәм 3 кибет эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1766 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Юмат волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 457 ир-ат; 1859 да — 683, 1908 дә — 773, 1920 дә — 1010 (Покровский а. халкын кертеп), 1926 да — 882, 1938 дә — 601, 1949 да — 344, 1958 дә — 282, 1970 тә — 312, 1979 да — 233, 1989 да — 467, 2002 дә — 514 кеше.

**«ТАТА́Р БӨГЕЛМӘСЕ́»**, тавык кроссы. 2002 елда Бөгелмә районы «Птицевод» нәсел заводында леггорн токымы нигезендә 3 линияле кросс формасында Д.Г.Ситдыйков, В.И.Фисинин, М.Ш.Алиев, Р.И.Варакина, В.Н.Ключникова һ.б. тарафыннан китереп чыгарыла. Кросс аутосекслы. Бер көнлек ата һәм ана чебешләр үзләренең тышкы күренешләре б-н аерылып торалар. Әтәч чебешләрнең канат йоннары тавык чебешләрнекенә караганда озынрак. Бу күренеш нәселдән нәселгә үзгәрешсез күчә һәм әтәч чебешләр алга таба үрчетелмәгәнлектән, практика өчен әһәмияте бик зур. Кросс экономия ягыннан да бик файдалы. «Т.Б.» тавыклары күп йомырка салу сыйфатына ия (1 елга 1 тавыкка — 313 данә, массасы — 60,5 *г*) һәм йомырка салуга аз азык бирәмлеге (1 мең йомыркага — 1,47 *ц*) сарыф итәләр, үсү вакытында үлем бары тик 1,8% тәшкил итә. Кросс Россиянең «Птицесоюз» берләшмәсе тарафыннан киң кулланышка тәкъдим ителгән.

*Әд.:* С и т д ы й к о в Д.Г. Новый аутосексный кросс в Татарстане // Птицеводство. 2000. № 2; Рекомендации по работе с аутосексным кроссом кур породы белый леггорн «Бугульма». Сергиев Посад, 2001.

*Р.Ә.Хәертдинов.*

**ТАТА́Р БУАСЫ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 4 *км* көнбатыштарак, Карлы елгасы буенда. 2010 елда 653 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Кош ф-касы. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Янтуган исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 198,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Ырынгы волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1795 тә — 136, 1859 да — 107, 1880 дә — 152, 1897 дә — 218, 1910 да — 290, 1913 тә — 317, 1920 дә — 352, 1926 да — 285, 1938 дә — 308, 1949 да — 260, 1958 дә — 304, 1970 тә — 500, 1979 да — 496, 1989 да — 475, 2002 дә — 625 кеше.

**ТАТА́Р БҮЛӘРЕ́** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 32 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сикия елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 381 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр, дәүләт крәстияннәре һәм асабалар катлауларына бүленә; игенчелек, терлекчелек, чана, тәгәрмәчләр һәм тугым ясау б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Т.Б.ндә мәчет, мәктәп, ашлык саклау-сату кибете эшли. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 217 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 июленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1816 да — 83, 1834 тә — 246 ир-ат; 1870 тә — 541, 1897 дә — 645, 1913 тә — 778, 1926 да — 756, 1938 дә — 614, 1949 да — 409, 1958 дә — 437, 1970 тә — 486, 1979 да — 474, 1989 да — 374, 2002 дә — 358 кеше.

**ТАТА́Р ГАДЕЛШАСЫ́** (Гаделша) авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Олы Бахта бассейнында урнашкан. 2010 елда 531 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә; лашманлыкта эшли, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Г.нда 2 мәчет (1864 һәм 1892 дә төзелә), 3 тегермән, ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1732 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Мөслим волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай

кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 146 ир-ат; 1859 да — 820, 1897 дә — 1260, 1908 дә — 1418, 1920 дә — 1049, 1926 да — 1353, 1938 дә — 891, 1949 да — 544, 1958 дә — 523, 1970 тә — 697, 1979 да — 561, 1989 да — 512, 2002 дә — 585 кеше.

**ТАТА́Р ГӨМБӘЗЕ́**, Татар мегаблогы, Гөмбәзсыман күтәрелмәләрнең татар системасы, ТРда иң эре тектоник структура. Батынкылыклар б-н бүлгәләнгән күтәрелмәләрдән (утырма токымнар буенча) һәм блоклардан (кристаллик нигез буенча) гыйбарәт. Төньяк (Кукмара, Төньяк-Татар) һәм көньяк (Әлмәт, Ромашкино, Көньяк-Татар) макроблокларын (биеклек амплитудалары утырма токымнар буенча 80 *м* дан кристаллик нигездә 5 *км* га кадәр һәм күбрәк гөмбәзләр) үз эченә ала. Күтәрелмәләр *Зәй-Сарайлы бөгелеше* (Кама буеның тирәндәге сындырмалары) б-н бүленә. Көньяк макроблок (гөмбәз) ике мезоблоктан: Әлмәт гөмбәзе һәм Акташ-Яңа Елховой өелмәсеннән тора, зур нефть чыганаклары, ш.и. Ромашкино һәм Яңа Елховой чыганаклары биредә урнашкан. Җир өслеге рельефында көньяк гөмбәзгә Бөгелмә калкулыгы туры килә. Т.г.нең утырма токымнарында нефть, битум, күмер, бакыр рудалары, минераль сулар һ.б. файдалы казылмаларның төп запаслары тупланган. Бер Т.г.урынына 2003 тән ике мөстәкыйль гөмбәз: *Төньяк Татар гөмбәзе* һәм Көньяк Татар гөмбәзе билгеләнә.

*Әд.:* Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003; Альметьевская энциклопедия. Т. 1. Природа Юго-Востока Республики Татарстан. К., 2006.

**ТАТА́Р ГУМАНИТА́Р ИНСТИТУТЫ́** (ТГИ), ТР Фән һәм мәгариф министрлыгының югары уку йорты. 1992 елда Татар көллияте буларак оештырыла, 1996 да Казанның 2 нче пед. уч-щесе б-н берләштерелә һәм Татар гуманитар ин-ты итеп үзгәртелә. ТР бюджетыннан финанслана торган беренче ике югары уку йортының берсе (Татар-Америка региональ ин-ты б-н беррәттән). Татар, башлыча, авыл мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү максаты б-н ачыла. Тарих, татар филологиясе һәм көнчыгыш телләр, урта махсус белем бирү ф-тлары эшли. Укыту югары (татар теле һәм әдәбияты, инглиз теле, тарих, пед. һәм башлангыч белем бирү методикасы) һәм урта һөнәри (башлангыч сыйныфларда укыту, мәктәпкәчә белем бирү) белем бирү белгечлекләре буенча алып барыла. 1,5 мең белгеч әзерли. 2005 тә ТГИ *Татар гуманитар-педагогика университеты* составына кертелә.

Җитәкчеләре: Ф.Ә.Галиева (1992–93), И.К.Заһидуллин (1993–97), В.Г.*Гайфуллин* (1997–2005).

*Әд.:* Загидуллин И.К. Дорогу осилит идущий (Татарскому государственному гуманитарному институту — 5 лет) // Уч. зап. Татар. гос. гуманитарного ин-та. 1997. № 1.

**ТАТА́Р ГУМАНИТА́Р-ПЕДАГО́ГИКА УНИВЕРСИТЕТЫ́** (ТГПУ). 2005 елда Казан пед. ун-ты, Татар гуманитар ин-ты, Татар-Америка региональ ин-тының пед. коллективларын һәм студентларын берләштерү юлы б-н булдырыла. Аның составында — табигыять-геогр., физ., матем., тарих, музыка, рус филологиясе, татар филологиясе, чит телләр, юриспруденция, сынлы сәнгать һәм дизайн, физкультура, социаль-икътисад (дөнья икътисады һәм милли икътисад, маркетинг, дәүләти һәм муниципаль идарә, коммерция, менеджмент, туризм буенча белгечләр әзерли) ф-тлары; Педагогика һәм психология ин-ты (башлангыч мәктәп һәм мәктәпкәчә белем бирү укытучыларын, психологлар, логопедлар әзерли). 2009/10 уку елында укыту 42 белгечлек буенча алып барыла. Көндезге бүлектә — 8100, читтән торып уку бүлегендә 4700 студент укый, шуларның 4600 е түләүле нигездә. 68 кафедрада 798 укытучы, ш.и. 76 фән. д-ры, 400 фән. канд. эшли.

2005 тән ТГПУ структурасында — гуманитар һәм пед. тикшеренүләр фәнни-тикшеренү ин-ты, ул региональ социаль-икътисади тикшеренүләр (терр. социаль-икътисади анализ һәм фаразлау, Евразия этноархеол. һәм социол.-табигый тикшеренүләр секторлары б-н), идарә итү, үсә торган организмның җайлашу проблемаларын, фәнни-мәгариф мәгълүмат ресурсларын һ.б.ны өйрәнү үзәкләрен үз эченә ала. 2009 да Мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм һөнәри яктан яңадан әзерләү ин-ты ачыла. 2010 да фәнни-тикшеренү ин-тында һәм кафедраларда 400 дән артык аспирант укый. 2011 дә Казан ун-ты структурасына керә. ТГПУның ректорлары: Җ.Г.Нигъмәтов (2005–08), Р.Р.Җамалетдинов (2008–2011).

Илл.не *Татарстан Республикасы* мәкаләсендә кара.

**«ТАТА́Р ДӘҮЛӘ́Т АКАДЕ́МИЯ ТЕА́ТРЫ МӘҖМУГА́ ПРОГРА́ММАСЫ»**, журнал; к. «*Тамашачы*».

**ТАТА́Р ДИМЕСКӘЕ́** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Дим елгасы буенда. 2010 елда 606 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1740 елларда Яңа Мәскәү юлындагы станция буларак нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Димескәй исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре һәм асабалар катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, почта хезмәтен башкара. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; 2 мәчет, мәктәп, земство станциясе, 3 су тегермәне, тимерчелек эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4859 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Димескәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 449, 1859 да — 971, 1889 да — 1527, 1897 дә — 1865, 1910 да — 2481, 1920 дә — 2481, 1926 да — 1994, 1938 дә — 1139, 1949 да — 835, 1958 дә — 722, 1970 тә — 915, 1979 да — 760, 1989 да — 681, 2002 дә — 675 кеше.

**ТАТА́Р ДИМЕСКӘЕ́ АЛАНЫ́**, ботаник табигать истәлеге. Бөгелмә р-ны терр-ясендә, Татар Димескәе авылыннан 5 *км* көнбатыштарак урнашкан. ТР рельефының аеруча калку өлеше (340 *м*). 1989 елда билгеләнә. Мәйданы 1,9 *га*. Урман буендагы болын-дала участогы. Үсемлекләрнең 100 дән артык, ш.и.



Татар Димескәе аланы.

сирәк төрләре: рус төймәбашы, матур кылган, сары җитен һ.б. үсә.

**ТАТА́Р ДӨМ-ДӨМЕ́** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 35 *км* төньяк-көнбатыштарак, Вятка елгасыннан 5 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 288 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Д.-Д.ндә волость идарәсе урнаша, мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2011 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Чиркәс волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 494, 1887 дә — 935, 1905 тә — 837, 1920 дә — 1077, 1926 да — 1026, 1938 дә — 853, 1949 да — 646, 1958 дә — 490, 1970 тә — 433, 1979 да — 365, 1989 да — 338, 2002 дә — 318 кеше.

**ТАТА́Р ДРА́МА ҺӘМ КОМЕ́ДИЯ ТЕА́ТРЫ** (К.Тинчурин исем. Татар дәүләт драма һәм комедия театры), Казанда. 1933 елда, авыл тамашачысына хезмәт күрсәтү максатыннан, Татар акад. театры ф-лы буларак оешса. 1938 дә 6 нчы колхоз-совхоз театрына үзгәртеп корыла, урнашу урыннары — Балтач авылы, 1939 ның декабреннән — Арча, 1942 нең октябреннән — Буа шәһәрләре; соңрак Буа шәһәр татар драма театры дип атала. 1944 нең октябрендә Казанга күчерелә һәм Татар дәүләт респ-ка күчмә театры дип үзгәртелә, 1979 дан — Татар драма һәм комедия театры, 1988 дән — К.Тинчурин исемендә. 1933 тә филиалның директоры һәм режиссёры итеп Мәскәү үзәк татар эшче театрының элекке актёры һәм режиссёры М.*Ильясов* билгеләнә, труппа составына Н.Арапова, Б.Әхтәмов, Г.Болгарская, Б.Галиуллина, Анна һәм Александр Гацулиннар, Г.Гыйматов,

З.Закиров, Ф.Ильская, Х.Исмәгыйлев, Г.Камская, И.Мәҗит, М.Рәхмәтуллина, А.Хисамов, И.Шаһдалиев, Ә.Яһудин кебек актёрлар керә. 1933 нең 6 ноябрендә Питрәч р-ның Шәле авылында «Булат бабай семьясы» (К.Нәҗми, К.Тинчурин) спектакле күрсәтелә һәм шуның б-н театрның эшчәнлеге башлана. Аннан соңгы берничә елда М.Ильясов тарафыннан «Ярату» (Н.Сәлахов), «Хаҗи әфәнде өйләнә» (Ш.Камал), «Алты гашыйк» («Шестеро любимых», А.Н.Арбузов) спектакльләре куела. Ш.Сарымсаков «Скапен хәйләләре» («Плутни Скапена», Ж.Б.Мольер), С.Булатов һәм Г.Уральский «Шәмсекамәр» (М.Әблиев), «Чик буенда» («Пограничники», В.Н.Билль-Белоцерковский) спектакльләрен куялар. 1937 дә М.Ильясов репрессияләнә, 1938 дән труппа б-н Ә.Мәҗитов җитәкчелек итә. Репертуарында «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш), «Аршин мал алан» (У.Хаҗибәков), «Урманда» (Ф.Хөсни), «Гөлзада» (Р.Ишморат) спектакльләре урын ала. Бер урыннан икенче урынга күчеп йөрүенә һәм авыр шартларга карамастан, театр мәгарифне үстерү, тамашачыга рухи һәм әхлакый тәрбия бирү бурычын үти. Бөек Ватан сугышы елларында труппаның ирләр составы кими, актрисаларга ир-ат рольләрен дә башкарырга туры килә. Шулай да «Серле казна» (Т.Гыйззәт), «Кайту» (Р.Ишморат), «Патриотлар семьясы» (Г.Насрый) спектакльләре дөнья күрә. Труппа З.Камалова, В.Минкина, С.Сәгыйтов кебек актёрлар б-н тулылана.

1946 да, Ә.Мәҗитов үлгәннән соң, театр б-н реж. Г.*Йосыпов* җитәкчелек итә. Ул сәхнәгә яңа чыккан спектакльләрне җәмәгатьчелек б-н карау һәм фикер алышуны гадәткә кертә. Аның тарафыннан куелган «Тормыш җыры» (М.Әмир) һәм «Украина далаларында» («В степях Украины», А.Е.Корнейчук; икесе дә — 1947; күчмә театрлар смотрларында 1 нче премиягә лаек булалар), «Яшьләр алдатмыйлар» (М.Фәйзи, 1946) спектакльләре зур иҗтимагый яңгыраш ала. 1950 дән театрның сәнгать җитәкчелеге башында торучы С.Вәлиев-Сульва куйган романтик спектакльләр популярлык казана. «Башмагым» (Т.Гыйззәт; Җ.Фәйзи муз., 1951), «Галиябану» (М.Фәйзи, 1952), «Сулган чәчәкләр» (Җ.Җаббарлы, 1953), «Чал чәчле кыз» («Седая девушка», Кытай драматургы Дин Ли, 1954), «Кара йөзләр» (М.Гафури повесте буенча, 1954) спектакльләре 1950 еллар репертуарының нигезен тәшкил итәләр. Бу елларда театрга директор М.Хәмзин, рәссам П.Баландин, актёрлар Х.Хәмзин, Р.Кушловская, К.Нуруллина, С.Мөхәррәмов, Татар театр уч-щесен тәмамлаган Г.Нуруллин, Л. һәм Ф.Фарсиннар, С.Исмәгыйлева, татар сәхнәсе корифейлары К.Шамил һәм М.Сульва киләләр. Театрны өч дистә ел буе аның сәнгати һәм иҗади үсешендә зур роль уйнаган һәм берничә буын актёрлар тәрбияләп чыгарган К.*Тумашева* (1956–62) һәм аның улы Р.*Тумашев* (1963–85) җитәкли. Реалистик ысул һәм психол. мәктәп тарафдарлары буларак, алар актёрлардан хисләр чынлыгын, характерларның эзлекле үстерелешен, тормышчанлык таләп итәләр. Бу эштә аларга Ә.Гаффар, Р.Батулла, Р.Мингалим, М.Мәһдиев драматургиясе ярдәмгә килә. Р.Ишморатның «Үлмәс җыр» (1957) пьесасы буенча куелган спектакль зур вакыйга буларак кабул ителә. «Рәйхан» (Н.Исәнбәт, 1960), «Беренче мәхәббәт» (Х.Вахит, 1960), «Йөрәк янар өчен бирелгән» (Т.Миңнуллин, 1970), «Сандугачлар килгән безгә» (И.Юзеев, 1974), «Ефәк баулы былбыл кош» (А.Гыйләҗев, 1982) спектакльләре дә уңыш казана. Театр Үзбәкстан, Кыргызстан, Казакъстан, Әзәрбайҗан респ-калары шәһәрләренә спектакльләр б-н чыга. Труппа яшь буын актёрлар (И.Мәхмүтова, Х.Мәхмүтов, Н.Шәйхетдинов, Р.Мифтахов, З.Харисов, М.Җаббаров, З.Досаева) б-н тулылана. Респ-кадан читтәге шәһәрләрдә танылу алган театрның еллар дәвамында тупланган осталыгы һәм казанган абруе аңа яңача караш, эшләү өчен иң яхшы шартлар тудыруны таләп итә. 1988 дә театрга элек Татар акад. театры эшләгән бина бирелә һәм ул стационар театр статусын ала. 1985–91 дә театр б-н Р.Батулла, Д.Сираҗиев, 1993 тән Б.В.Щукин исем. Югары театр уч-щесен (Мәскәү) тәмамлаган реж. Р.Заһидуллин җитәкчелек итә. Үз спектакльләрен ул яңа ритмнар, хәрәкәт, көчле театральлек һәм тамашалылык, уен дәрте б-н баета, төрле жанрлар һәм стилистикада актёрларның иҗади мөмкинлекләрен ача, театрның үзенчәлекле реформаторына әверелә. Н.Фәттах романы буенча сәхнәләштерелгән «Идел суы ака торур» (1993) спектаклендәге эпик киңлек, К.Тинчурин пьесалары буенча куелган «Хәйләсез — дөнья файдасыз» (1992), «Назлы кияү» (1996), «Хикмәтле доклад» (2003), «Американ» (2007) спектакльләрендәге көчле гротеск, П.Бомаршеның «Тынгысыз төн, яки Фигароның өйләнүе» («Женитьба Фигаро», 1995) һәм Ж.Б.Мольерның «Галиҗәнап де Пурсоньяк» («Господин де Пурсоньяк», 1999) пьесалары буенча куелган спектакльләрдәге ачыктан-ачык театральлек, И.Грекова повесте буенча сәхнәләштерелгән «Тол хатыннар көймәсе» («Вдовий пароход», 1994) һәм Х.Вахит пьесасы буенча куелган «Яңадан мәхәббәт турында» (1998) спектакльләрендәге психол. тирәнлек актёрлардан төрле уен алымнары һәм чараларыннан файдалануны, сәнгатьчә сурәтләү чаралары диапазонын киңәйтүне таләп итә. «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин, 1999), «Кураж ана һәм аның балалары» («Мамаша Кураж и её дети», Б.Брехт, 2000), «Кояш төшмәгән җирдә» («На дне», М.Горький; 2005), «Бернарда Альба йорты» («Дом Бернарды Альбы», Г.Лорка; 2008) кебек спектакльләрнең сәхнәгә чыгуы коллективның зур иҗат тәҗрибәсе туплавын раслый, театрның сәнгати үсеш дәрәҗәсен билгели. Болардан тыш соңгы елларда театр сәхнәсендә «Кияүләр», «Туй алдыннан» (Х.Вахит), «Хаҗи әфәнде өйләнә» (Ш.Камал), «Әти балак Гөлүзә» (Ю.Әминов), «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов), «Алтын көз» (Ш.Фәрхетдинов, Р.Заһидуллин), «Төн яна уяакта» (Х.Ибраһим), «Гайфи бабай, өйлән давай!» (Г.Зәйнашева),




К.Тинчурин исем. Татар драма һәм комедия театры.



М.Гафуриның «Кара йөзләр» повесте буенча куелган спектакльдән күренеш. К.Тинчурин исем. Татар драма һәм комедия театры. 1954.







К.Тинчурин исем. Татар драма һәм комедия театры спектакльләреннән күренешләр: 1.«Идел суы ака торур», Н.Фәттах. 1993; 2. «Соңгы риваять», М. Маликова. 2014; 3. «Кара Пулат» операсы, Р.Харис, Э.Низамов. 2015.

«Мәхәббәт чишмәсе», «Күрәсем килгән иде...» (И.Мәхмүтова), «Төш» (Т.Миңнуллин), «Бер тамчы ярату» (Н.Гыйматдинова), «Язмышым юллары» (Р.Вәлиев), «Бер көрешү — үзе бер гомер» (Ф.Яруллин), «Өзелгән яфраклар» (Р.Габделхакова), «Соңгы риваять» (М.Маликова), «Йосыф-Зөләйха» (Н.Хисамов), «Без барыбыз да кешеләр» («Все мы люди», Эрих Мария Ремарк романы буенча), «Гамлет. Күренешләр» («Гамлет. Сцены», У.Шекспир), «Кара Пулат» (Р.Харис, Э.Низамов; «Ел вакыйгасы» номинациясендә ТР Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләге лауреаты, 2015), «Чулпан» (Ш.Хөсәенов), «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов), «Түләк» (Н.Исәнбәт), «Өченче бүлмәдә эт яши» (Р.Мингалим), «Кичер мине» («Прости меня», И.Герман), «Беренче мәхәббәт» (И.Гали), «Әллә язмыш, әллә ялгыш» («Выйти замуж», Н.Нестерова повесте буенча) һ.б. спектакльләр дә зур уңыш б-н бара. Театр ТР һәм РФ шәһәрләре һәм районнары буйлап гастрольләрдә йөри, Россия һәм халыкара театр фестивальләрендә катнаша, К.Тинчурин исем. чираттагы VIII Халыкара милли драматургия театр фестивален уздыра (2016).

2015 тә труппа составында — РФ һәм ТРның халык артисты Н.Шәйхетдинов; РФнең атказ. һәм ТРның халык артисты И.Мәхмүтова; ТРның халык артистлары Җ.Әсфәндиярова, Ә.Галиуллин, Т.Зиннуров, З.Харисов, Л.Миңнуллина, И.Хәсәнов, Н.Нәҗмиев, З.Хәкимҗанова, Т.Фәйзуллина, Р.Төхфәтуллина; ТРның атказ. артистлары З.Вәлиева, Л.Галләмова, Г.Гарәпшина, З.Зарипова, Л.Мәхмүтова, С.Мифтахов, М.Нәҗмиева, Г.Нәүмәтова, И.Сафиуллина, Ш.Фәрхетдинов, Ә.Хәсәнова, Р.Шәмсетдинов; актёрлар Г.Гайнуллина, А.Пискунов, Р.Сәлахова, А.Фәтхуллин, Х.Хөснетдинов һ.б. Театрның баш режиссёры — РФнең атказ. артисты, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе Р.М.*Заһидуллин* (1993 тән); директоры — Ф.Н.Мөсәгыйтов (2002 дән).

*Әд.:* Иллялова И. Театр имени Тинчурина. К., 2002. *И.И.Иллялова.*

**ТАТА́Р ДРАМАТУРГИ́ЯСЕ**, 19 йөзнең соңгы чирегендә барлыкка килә. Беренче пьесалар арасында — Г.Ильясиның «Бичара кыз», Ф.Халидинең «Рәдде бичара кыз» мелодрамалары, билгесез авторның рус теленнән ирекле тәрҗемәдә «Комедия Чистайда» комедиясе, М. әл-Казаниның романтик-маҗаралы «Ихтыярлы кыз ихтыярсыз улмыш» драмасы, Г.Камалның «Өч бәдбәхет», «Бәхетсез егет» драмалары, Г.Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш» драмасы. Бу пьесаларда мәгърифәт, шәхес, аеруча хатын-кыз иреге мәсьәләләре яктыртыла, яшәештә искелек билгеләре, наданлык ише күренешләр тәнкыйть ителә. Тулаем алганда, алар реаль тормышны чагылдыра. Ләкин аларның поэтикалары әле камиллектән ерак тора, бу хәл сюжет сызыгын һәм образлар системасын төзүдә күренә. 20 йөз башы Т.д.ндә (Я.Вәлинең «Оят, яки Күз яше», Ф.Халидинең «Залим ачлык, Испанияле Сәед Яхъя бәянында», «Морат Сәлимов», «Мәхрүсә ханым», И.Богдановның «Зөләйха белән Фатыйма») бу кимчелекләрдән арынуга омтылыш сизелә. Т.д.нең әдәби традицияләре синтезы, тасвирланган күренешләрнең һәм геройларның чынлыгы 1905–07 еллардагы рев-ция чоры пьесаларында ачык чагыла. Идея-эстетик принципларның һәм жанр поэтикасының формалашуында тәрҗемә әсәрләр зур роль уйный: Н.В.Гогольның «Өйләнү» («Женитьба»), «Ревизор» пьесалары, төрек язучысы Н.Кямалның «Кызганыч бала» (Г.Камал тәрҗемәсе), А.Н.Островскийның «Наданлык илә галимлек» («В чужом пиру похмелье»), «Ярлылык гаеп түгел» («Бедность не порок») пьесалары, А.П.Чеховның «Кыз сорау» («Предложение») водевиле һ.б. Татар проф. театрының барлыкка килүе (1906 ның марты) Т.д. үсешендә хәлиткеч фактор була. Аның репертуарында төп урынны Г.Камал һәм Г.Исхакый әсәрләре били. Яңа сәнгать алымнары б-н драма жанрын Г.Коләхмәтов баета. Аның «Ике фикер», «Яшь гомер» пьесаларының төп персонажлары — эшче сыйныф һәм интеллигенция вәкилләре, татар җәмгыяте өчен яңа булган социалистик идеология тарафдарлары. Бу пьесаларда беренче мәртәбә интернационализм темасы күтәрелә. Аллегорик образлар («кара» һәм «кызыл» фикерләр) аша Г.Коләхмәтов милли драмага тормышны яңача чагылдыру алымнарын кертә.

Драма жанрында Г.Исхакый («Ике гыйшык», «Мөгаллим», «Алдым-бирдем»), Г.Камал («Бәхетсез егет», «Уйнаш»), Я.Вәли («Ачлык кушты»), Ф.Әмирхан («Яшьләр»), С.Рәмиев («Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!») һ.б. актив иҗат итәләр. Әлеге авторларның пьесаларында рев-ция һәм аннан соңгы чордагы милли яшәешнең төрле яклары чагылыш таба. Иң актуаль тема — яңалыкның искелеккә каршы торуы.

1910 елларда Т.д.нең яңадан-яңа жанрлары һәм жанр формалары барлыкка килә: тарихи драма (Ф.Туйкин, «Ватан каһарманнары»), романтик драма (Г.Исхакый, «Мөгаллимә»; М.Фәйзи, «Кызганыч»), психол. драма (Г.Исхакый, «Зөләйха»), муз. драма (М.Фәйзи, «Галиябану», Ф.Бурнаш, «Яшь йөрәкләр»); трагедия (Ф.Бурнаш, «Таһир-Зөһрә») һ.б. Тематиканы киңәйтү, проблематиканы кискенләштерү тенденциясе көчәя. Беренче планга милләт язмышы мәсьәләсе чыгарыла, үзләрен халыкка хезмәт итүгә багышлаган геройлар пәйда була. Пьесалар фикер ирегe, патриотизм, гаделлек, тугрылык, мәхәббәт һ.б. гомумкешелек кыйммәтләрен раслый. Г.Камал («Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре»), Г.Исхакый («Кыямәт», «Җәмгыять»), И.Богданов («Помада мәсьәләсе»), Ш.Камал («Хаҗи әфәнде өйләнә»), К.Тинчурин («Назлы кияү») комедияләре — татар әдәбиятында тәнкыйди реализмның уңышлы үрнәкләре. Аларда татар җәмгыятендәге иске тәртипләр тәнкыйтьләнә, кешедәге кимчелекләр сатира утына тотыла.

Окт. рев-циясеннән соң Т.д. ике юнәлештә үсә. Эмиграциядәге язучылар — Г.Исхакый («Ике ут арасында», «Жан Баевич», «Олугъ Мөхәммәд», «Хәят юлында»), Х.Хәмидулла («Ник болай?»), Х.Габдүш («Татар телендә беренче телеграф») һ.б., татар әдәбияты традицияләрен дәвам итеп, әсәрләрендә милли һәм гомумкешелек мәсьәләләрен яктырталар.

Совет Россиясендә Т.д. татар театр сәнгате б-н тыгыз бәйләнештә үсә. К.Тинчуринның 1920 елларда язылган «Йосыф-Зөләйха», «Сакла, шартламасын!», «Американ», «Җилкәнсезләр», Н.Исәнбәтнең «Һиҗрәт» һ.б. комедияләренә иске тормышны кискен тәнкыйтьләү хас. Ф.Бурнашның «Камали карт», «Илһам», К.Әмиринең «Печән базары», «Казан кызы» комедияләрендә, Һ.Такташның «Югалган матурлык», «Камил» драмаларында үткәндәге яшәеш кимчелекләре б-н беррәттән тормышта һәм кешеләр аңында барлыкка килгән яңалык сыйфатлары да урын ала. «Культур Шаңгәрәй», «Пикуләй Шәрәфи», «Портфель» комедияләрендә Н.Исәнбәт совет чынбарлыгының кимчелекләреннән көлә. Бу елларда рев-ция һәм гражданнар сугышы темасы аеруча актуаль була. Ш.Усмановның «Канлы көннәрдә», «Бай кызы», Ф.Сәйфи-Казанлының «Дошманнар», Ф.Бурнашның «Адашкан кыз», «Хөсәен мирза», Һ.Такташның «Күмелгән кораллар», Ш.Камалның «Ут», Т.Гыйззәтнең «Наёмщик» драмаларында, С.Рахманколый, Ф.Бурнаш һ.б.ның мелодрамаларында революция вакыйгалары үзәгендә хезмәт ияләренең социаль азатлыгын бөтен дөнья байлыкларыннан һәм шәхси мәнфәгатьләрдән өстен куючы, яңача фикерләүче геройлар урын ала.

1930 елларда Т.д.нең тематикасы киңәя һәм сәнгать чаралары б-н баый. Т.Гыйззәтнең («Чаткылар», «Бишбүләк», «Ташкыннар»), Ш.Усмановның («Кичеккән фәрман»), Н.Исәнбәтнең («Спартак», «Идегәй»), Ф.Бурнашның («Лачыннар», «Таң»), Ә.Фәйзинең («Пугачёв Казанда», «Тукай») һ.б.ның тарихи һәм тарихи-биографик пьесаларында социаль конфликтлар чагыла, пьеса геройлары — көчле рухлы революционерлар, сыйнфый гаделлек өчен көрәшүчеләр. Ләкин бу образларга еш кына сәнгать ягыннан камиллек җитешмәү, схемалылык хас. Бу унъеллыкның икенче үзенчәлеге — халык иҗатына игътибар арту, фольклор сюжетларына нигезләнгән әдәби әсәрләр язылу. Н.Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу», «Хуҗа Насретдин», Т.Гыйззәтнең «Кыю кызлар», М.Әмирнең «Көнлекче Әхмәт һәм аның матур хатыны» һ.б. пьесаларда халык әкиятләре һәм мәзәкләрләреннән алынган геройларның күпчелеге иҗтимагый комедия алымнары б-н тасвирлана.

Колхозлар төзү, индустрияләштерү Т.Гыйззәтнең («Данлы көннәр»), Ф.Бурнашның («Тукучы Әсма» һәм «Ялгыз Яруллa»), Ш.Камалның («Габбас Галин»), Ф.Сәйфи-Казанлының («Зөбәрҗәт»), Г.Иделленең («Дәүләт Бәдриев») драма һәм комедияләре язылу өчен чыганак була.

1941–45 еллардагы совет халкының немец-фашистларга каршы алып барган героик көрәше М.Әмир («Миңлекамал», «Тормыш җыры»), Т.Гыйззәт («Төнге сигнал», «Изге амәнәт»), Н.Исәнбәт («Мәрьям»), Ф.Кәрими («Шакир Шигаев»), Р.Ишморат («Кайту») һ.б.ның пьесаларында чагыла. Сәхнәгә фронт һәм тыл геройлары, ватан сакчылары,

фидакарь хезмәт ияләре, патриотлар чыга. Сугыш темасы сугыштан соңгы елларда да игътибар үзәгендә була (Т.Гыйззәт, «Чын мәхәббәт»; М.Әмир, «Җыр дәвам итә»; Н.Исәнбәт, «Муса Җәлил»; Р.Ишморат, «Үлмәс җыр» һ.б.).

1950–60 еллардагы совет сәнгатендә Т.д.нә сизелерлек зыян китергән «конфликтсызлык теориясе» өстенлек итә. Бу хәл бигрәк тә заман темаларына язылган әсәрләрдә ачык чагыла. «Яхшы»ның «бик яхшы» б-н тартышуын гәүдәләндергән пьесалар чынбарлык каршылыкларын тулы күрсәтә алмый. Шуңа да карамастан, театр тарихында сизелерлек эз калдырган пьесалар туа: Н.Исәнбәтнең «Зифа», Р.Ишморатның «Алар дүртәү иде», Г.Насрыйның «Яшел эшләпә», Ю.Әминовның «Язылмаган законнар» һ.б. Театр тормышына Х.Вахит пьесалары бертөрле җанлану кертә. Аның «Беренче мәхәббәт», «Кайда соң син?», «Соңгы хат», «Күк капусы ачылса», «Туй алдыннан», «Ике килен-килендәш» һ.б. драма һәм комедияләренең игътибар үзәгендә — яшьләр мәсьәләләре. Тамашага корылган, муз. бизәлешле Х.Вахит пьесаларын тамашачылар яратып карый.

1970–80 еллар — Т.д.нең күтәрелеш чоры. Т.Миңнуллин («Миләүшәнең туган көне», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Үзебез сайлаган язмыш», «Монда тудык, монда үстек»), Ш.Хөсәенов («Әни килде»), А.Гыйләҗев («Җиргә тапшырылган серләр»), И.Юзеев («Сандугачлар килгән безгә», «Кыр казлары артыннан»), Ю.Әминов («Кан кардәшләр»), Р.Мингалим («Кайда сез, ирләр?») һ.б.ның пьесаларында заманның актуаль проблемалары күтәрелә. Аларда беренче планга шәхси омтылышлар һәм гомумкешелек кыйммәтләре чыга, халык традицияләренә игътибар арта.

1980 еллар урталарыннан җәмгыятьтә башланган тирән үзгәрешләр Т.д.нә көчле йогынты ясый. Агымдагы процессларга бәя әхлак, этика нормалары күзлегеннән чыгып бирелә башлый (А.Гыйләҗев, «Өч аршын җир»; Т.Миңнуллин, «Гармун белән скрипка»; И.Юзеев, «Ак калфакны төшердем кулдан» һ.б.). Кичәге һәм бүгенге кеше арасындагы каршылыклар, аларның җәмгыять үсеше б-н бәйле булуы, ул каршылыкларның тискәре характерда икәнлеген аңлау Т.Миңнуллинның «Хушыгыз!», З.Хәкимнең «Җүләрләр йорты», «Күрәзәче», Д.Салиховның «Алла каргаган йорт», М.Гыйләҗевнең «Бичура», Р.Хәмиднең «Кайтыр идем», Ф.Садриевның «Ач тәрәзәң», Ю.Сафиуллинның «Пар канат» пьесаларында чагылыш таба. Т.Миңнуллинның «Әниләр һәм бәбиләр», «Илгизәр плюс Вера», «Шәҗәрә» пьесалары үзәгендә — милләт язмышы, туган телне саклап калу проблемасы. Татар халкының үткәненә, тарихи шәхесләренә игътибар арта: Ю.Сафиуллинның «Идегәй» («Идегәй» эпосы буенча), Т.Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз», Р.Батулланың «Сират күпере» әсәрләре. Илдәге сәяси вазгыять, аерым алганда, Чечнядагы сугыш трагедия жанрын активлаштыра (Ә.Баян, «Алтын ташбау»; Р.Хәмид, «Хан кызы Хансөяр»; Ю.Сафиуллин, «Йөзек һәм хәнҗәр»). Драманың төрле төрләре үсеш ала: психол. драма (Т.Миңнуллин, «Әзләдем, бәгърем, сине»), публицистик драма (Т.Миңнуллин, «Моңлы бер җыр», Ә.Гаффар, «Бер картлыкта, бер яшьлектә»), сәяси драма (И.Юзеев, «Ак калфакны төшердем кулдан»), социаль драма (Ф.Бәйрәмова, «Безне онытмагыз»), тарихи-библиографик драма (Ә.Гаффар, «Соңгы сәгать»). Беренче тапкыр монодрамалар языла: «Озын юлның тузаны» (Р.Хәмид), «Каракош» (Ә.Баян). 1970 елларда ук актив үсеш алган комедия (Н.Исәнбәт, «Кырлай егете»; Т.Миңнуллин, «Әлдермештән Әлмәндәр») яңа жанр формалары б-н баетыла: социаль комедия (А.Гыйләҗев, «Көттереп искән җил»), лирик комедия (Р.Мингалим, «Кунак кызы гел килмәс»), сатирик комедия (Р.Вәлиев, «Автомобиль, автомобиль»; З.Хәким, «Кишер басуы»), муз. комедия (М.Гыйләҗев, «Казан егетләре»; Ф.Яруллин, «Сөембикә егет сайлый») һ.б. Заманның актуаль мәсьәләләрен драматурглар трагикомедия (Ф.Садриев, «Кондырлы кодачасы»), мелодрама (Р.Батулла, «Кичер мине, әнкәй»; З.Хәким, «Мин сине яратам»), водевиль (Т.Миңнуллин, «Йөрәк маем») жанрларында да яктырталар. Т.д.ндә яңа жанр формалары барлыкка килә: трагипамфлет (Р.Батулла, «Мин Америка ачтым»), трагифарс (Г.Каюмов, «Мирас»), трагикомик фарс (З.Хәким, «Җен бутады») һ.б.

20 йөз ахырында – 21 йөз башында Т.д.сенә бер төркем яңа буын иҗатчылар килә (Аманулла, Ф.Галиев, М.Гыйләҗев, Р.Зәйдулла, И.Зәйниев, Х.Ибраһим, Г.Каюмов, Р.Корбан, Л.Лерон, Р.Сабыр, Д.Салихов, Р.Сәгъди, Э.Яһудин һ.б.). Авторлар әсәрләре, нинди генә жанрга яки жанр төренә карамасын, сәнгать ягыннан төрле алымнар, чаралар, детальләр ярдәмендә баетыла. Бигрәк тә сәнгати шартлылык киң кулланыла. Сирәгрәк булса да, романтик пафоска мөрәҗәгать итү урын ала (И.Юзеев, «Ахырзаман гашыйклары»; Г.Каюмов, «Ул» һ.б.). Модернистик алымнардан, яңа мифологик образлардан киң файдаланып язылган пьесалар ешая бара (Ю.Әминов, «Әҗәлнең үлеме»; З.Хәким, «Шайтан куентыгы»; М.Гыйләҗев, «Бичура»; Р.Зәйдулла, «Шул булды эш...» һ.б.). Шигъррият өчен характерлы символика һәм метафорикадан драматурглар иркен файдаланалар.

*Әд.:* Октябрьгә кадәр татар театры. К., 1988; Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. К., 1984–2001; Г и з з а т Б. Татарский театр // История советского драматического театра. М., 1971. Т. 1; История татарской советской литературы. М., 1983; Х а н з а ф а р о в Н.Г. Татарская комедия. К., 1996; А х м а д у л л и н А.Г. Татарская драматургия: история и проблемы. К., 2012.

*А.Г.Әхмәдуллин.*

**ТАТА́Р ЗАПА́С БАТАЛЬОНЫ́**, Респ-ка Революцион Хәрби Советы (РВС) рәисе Л.Д.Троцкийның 6 май күрсәтмәсе, Идел буе округы һәм Казан губернасы хәрби комис-тларының 1919 ел 9 һәм 11 май боерыклары нигезендә 1919 ның маенда Казанда оештырыла. Идел буе татар укчыларының 1 нче аерым бригадасы, 1919 ның октябреннән Төркестан фронты, 1920 нең октябреннән Респ-ка Запас армиясе карамагында була. Командирлары: М.Х.Таһиров, Я.Х.Исмаев, А.Х.Алмаев, А.Насыйбуллин, М.Ш.Шаһиәхмәтов; хәрби комиссарлары: Б.Җиһаншин, А.Г.Ганиев. Дүрт ротадан тора. Казан губернасында мобилизацияләнгән татарлардан туплана; өйрәнүләрдән (хәрби эш, сәяси белем һ.б.) соң алар Кызыл Армиядәге татар хәрби частьларын тулыландыралар. 1920 нең октябрендә Татар запас полкы дип үзгәртелә (6 батальоннан тора). Полкта комендант, пулемёт, хуҗалык, сапёр һәм телеграф командалары, кече команда составы әзерләү мәктәбе була. 1920 нең ноябрендә 90 марш ротасы (22,5 мең кеше чамасы); башлыча, Идел буе татар укчылар бригадасының 1 нче һәм 2 нче бүлекләрен тулыландыру өчен әзерләнә.

*Әд.:* Г и з з а т у л л и н И.Г. Мусульманские военные организации (1917–1921 гг.). К., 2002.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**ТАТА́Р ЗОНА́ЛЬ ТӘҖРИБӘ́ СТА́НЦИЯСЕ** посёлогы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 41 *км* төньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 187 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 57%, татарлар — 40%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, бакчачылык. 1940 елларда нигез салына. Оешкан көненнән Тәмте р-нында. 1958 нең 16 июленнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1958 дә — 335, 1970 тә — 407, 1979 да — 338, 1989 да — 186, 2002 дә — 226 кеше.

**ТАТА́Р ИҖТИМАГЫ́Й ҮЗӘГЕ́** (ТИҮ), к. *Бөтенроссия татар иҗтимагый үзәге* (БТИҮ).

**ТАТА́Р ИКШЕРМӘСЕ́** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 21 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 269 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1680 нән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Икшермә буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәктәп, су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1521,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әбде волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 108 ир-ат; 1859 да — 637, 1897 дә — 952, 1908 дә — 1026, 1920 дә — 1040, 1926 да — 1141, 1938 дә — 689, 1949 да — 540, 1970 тә — 562, 1979 да — 438, 1989 да — 403, 2002 дә — 331 кеше.

**ТАТА́Р ИКЪТИСАДИ́ ФИКЕРЕ́**, 19–20 йөзләр чигендә формалашкан иҗтимагый фикер юнәлеше; гамәлдәге хуҗалык эшчәнлегенә җайлашу буенча практик тәкъдимнәр эшли. Татар фикер ияләре тарафыннан базар мөнәсәбәтләренең асылын ачкан, җәмгыять ихтыяҗын чагылдырган милли социаль-икътисади әдәбият тудырыла. Ул монография-

ләр, «Икътисад», «Русия сәүдәсе» икътисади ж-ллары, күпсанлы иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета-журналларда махсус рубрикалар, танылган эшмәкәрләр династияләре турында тарихи-икътисади очерклар басылган брошюралар һ.б. рәвешендә тәкъдим ителә. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында әлеге темага багышланган күп кенә мөһим монографияләр басылып чыга. шулар арасында — тарихчы, икътисадчы һәм публицист Г.Фәезхановның «Китаби мәҗалис әс-сәрват вәл-мәгаш» (1890), «Фикер уятучы» (1893); галим-икътисадчы М.*Акъегетнең* «Икътисад, яки Байлык турындагы фән: ирекле сәүдә һәм аны яклау чаралары» (1892), «Байлык турындагы фән, яки Икътисад турындагы фән» (1900); М.Сәйфелмөлековның «Икътисад тарихында процент мәсьәләсе» (1915–1916 елларда «Шура» ж-лында басыла) хезмәтләре. 1906–07 дә «әл-Гаср әл-җәдид» ж-лында татарчага яңа татар әдәбиятына нигез салучыларның берсе Г.Тукай тәрҗемәсендә Россиянең булачак зур галиме акад. А.Н.Бахның «Икътисади очерклар. Ачлык патша» («Экономические очерки. Царь-голод») китабы басылып чыга.

Г.Фәезхановның «Китаби мәҗалис...» хезмәтендә үзәк урында — җитештерү, бүлү һәм алмашу мәсьәләләре. Аларга анализ ихтыяҗ, хезмәт, җитештерү эшчәнлеге, эш бүленеше, җитештерүдә махсуслашу һәм кооперация, капитал һәм аның динамикасы, табыш һәм аның бүленеше, эш хакы һәм аның формалары, сәүдә үсеше, җир рентасы, товар һәм аның үзлекләре, товарның кыйммәте, бәясе, формалашу механизмы, конкуренция һәм аның төрләре, банклар, акционерлар җәмгыятьләре, ширкәтләр кебек икътисад фәненең төп категорияләре призмасы аша бирелә. Фән, мәгариф, мед., мәдәният, халык тормышының социаль шартлары ш.у. автор тарафыннан иҗтимагый җитештерү һәм җәмгыятьнең алга китешен тәэмин итү системаларында иң мөһим факторлар буларак карала. Г.Фәезханов икътисад кануннарының объективлыгын таный, алар арасында вакытны экономияләү законын иң әһәмиятлесе дип, аныңча әйткәндә, «законнар законы» дип саный. Г.Фәезхановның карашлар системасы нигезләнгән теоретик-методологик принциплар классик икътисади мәктәп принципларына (аеруча А.Смитның «Халыклар байлыгының асылы һәм сәбәпләре турында тикшеренү» — «Исследование о природе и причинах богатств народов» фундаменталь хезмәтендә бәян ителгән идеяләргә) якын. Г.Фәезхановның монографиясе — икътисад белеменең генә түгел, философия, биол., механика, физика, табигатьтән файдалану өлкәсендәге башка фәнни-мәгърифәт белемнәренең дә мөһим чыганагы.

Дөньяның икътисади үсешен һәм хуҗалык элемтәләренең эволюциясен М.Акъегетзадә үзенең «Байлык турындагы фән...» һәм «Икътисад, яки Байлык турындагы фән...» монографияләрендә тикшерә. Дәүләтнең икътисади иминлеге мәсьәләләрен өйрәнгәндә ул А.Смит, Д.Рикардо, Ф.Лист хезмәтләренә, дөньяның гамәли тәҗрибәсенә, дөнья сәүдәсе үсеше тарихына мөрәҗәгать итә һәм, Смит б-н Рикардоның сәүдә иреге концепциясен дә, Листның протекционизм концепциясен дә вакыт контекстыннан тыш бәяләргә ярамый, чөнки тегесе дә, бусы да икътисади үсеш дәрәҗәсенең шул замандагы ихтыяҗларына гына җавап биргән, дигән нәтиҗәгә килә. Галим фикеренчә, билгеле бер шартларда ачык ишекләр сәясәте һәм протекционизм бергәлеге дә мөмкин һәм максатка ярашлы. Милли икътисадның нәтиҗәлелеге һәм яклануы өчен зарур шарт — аның комплекслы үсеше, ди ул.

«Икътисад» һәм «Русия сәүдәсе» ж-ллары, рус һәм дөнья икътисади фәне казанышларына таянып, Россиядәге һәм чит илләрдәге җитештерү тәҗрибәсен файдаланып, сәнәгать җитештерүе, сәүдә, җир эшкәртү, капитал үсеше, аның көндәшлеккә сәләтлелеге һәм куллану өлкәсен киңәйтү мәсьәләләрен карыйлар. Татар эшмәкәрләренең киң даирәсе өчен алар икътисади мәктәбе була. Журнал битләрендә алдынгы идеяләр пропагандалана: уку, һөнәри белемнәр алу, эшләрне югары дәрәҗәдә һәм файдалы итеп алып бару; машиналарны, җитештерүнең яңа алымнарын һәм технологияләрне күбрәк файдалану; җитештерү һәм сәүдәне оештыру һәм идарә итүнең камилрәк формаларын гамәлгә кертү; ширкәтләр, АҖләре, эшмәкәрләр берлекләре төзү.

Татар социаль-икътисади әдәбиятында җәмгыятьнең социаль структурасына туры килгән төрле идея агымнары яши. Аларны татар халкының рухи яңару юлларын һәм шартларын эзләүгә, аны ил һәм дөнья икътисады, фәне, техникасы, мәдәнияте казанышларына кушуга төбәлгәнлек берләштерә. Җәмгыятьнең эволюцион үсешенә, реформаларга юнәлеш өстенлек итә. Милли икътисади фикернең үзенчәлекләреннән берсе — социаль-икътисади проблемаларга дини карашлардан якын килү. Бу аеруча «милли» банк ачу һәм процент алу мәсьәләсендә калку чагыла. Шәригать кануннары кредит биргәндә мөселманнарга бер-берсеннән процент алуны тыя. «Икътисад», «Шура» ж-лларында һ.б. матбугат чараларында әлеге мәсьәлә тирәсендә бәхәсләр туа. Күп кенә мөселман дәүләтләренең (Малайзия, Согуд Гарәбстаны, Филиппин һ.б.) динамик үсеше генә түгел, кайбер алга киткән Көнбатыш һәм Көнчыгыш илләренең (АКШ, Япония) процентсыз кредит алудагы гамәли адымнары да хәзерге икътисади һәм социаль проблемаларны хәл итүдә аның актуальлеген күрсәтә. Т.и.ф.нең формалашуына Ф.Мортазин, Ш.Шәһидуллин, Х.Ямашев, М.Вахитов, Г.Коләхмәтов, Ш.Мөхәммәдов, И.Алкин, Г.Шәрәф, Р.Фәхретдин, Г.Баязитов, М.Бигиев һ.б. кебек татар халкының күренекле вәкилләренең хезмәтләре дә сизелерлек өлеш кертә. Татар халкының социаль икътисади фикере, аның формалашу һәм үсеш тарихы ил һәм дөнья икътисади фикере тарихының бай эчтәлекле сәхифәсен тәшкил итә.

Т.и.ф. мәсьәләләрен тикшерү алга таба Ф.Г.Газизуллин, М.З.Гыйбадуллин, Г.Н.Һадиуллина хезмәтләрендә чагылыш таба. Икътисадның ТР Президенты М.Ш.Шәймиев тәкъдим иткән базар мөнәсәбәтләренә акрен-ләп керү концепциясе милли икътисади фикер үсешенә сизелерлек өлеш була. Россия һәм Татарстанның социаль-икътисади үсеше, аларның икътисадын оптимальләштерүнең инновацион юлына күчерү, икътисад һәм экология бәйләнешенең, ресурсларны нәтиҗәле файдалану, җитештерелә торган продукциянең көндәшлеккә сәләтлелеген күтәрү һ.б. проблемалар Ф.Г.Хәмидуллин, Н.Г.Газизуллин, М.Р.Сафиуллин, А.Ш.Хәсәнова, Ф.С.Зыятдинов, Р.К.Мәҗитова, Р.А.Нугаев хезмәтләрендә өйрәнелә.

*Әд.:* Ф у к с К.Ф. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. К., 1844; История русской экономической мысли: В 3 т. М., 1955–66; Г а з и з у л л и н Ф.Г. Фаизханов и формирование системы экономических взглядов в татарской литературе // Уч. зап. Казан. гос. пед. ин-та. 1975. Вып. 141; ш у л у к. Дорогой к правде. К., 1979; ш у л у к. Муса Акъегет — видный учёный-экономист, представитель зарубежной татарской диаспоры // 2 Всемирный конгресс татар (Второй созыв): 28–29 авг. 1997 г. К., 1998; ш у л у к. Социально-экономическая мысль татарского народа как феномен его духовной культуры. К., 1999; ш у л у к. Становление и развитие социально-экономической мысли татарского народа. СПб., 2004; Х а с а н о в Х.Х. Формирование татарской буржуазной нации. К., 1977; А м и н о в Д.А. Татары в Санкт-Петербурге: Ист. очерк. СПб., 1994; Х а д и у л л и н а Г.Н. Экономические идеи в наследии Мусы Акъегетзаде. 1864–1923. К., 2003; ш у л у к. Экономические воззрения представителей татарской зарубежной диаспоры. М., 2003.

*Ф.Г.Газизуллин.*

**«ТАТА́Р ИЛЕ́»**, газета; к. *«Татарские края» — «Татар иле».*

**«ТАТА́Р ИЛЕ́»**, *Вюнсдорф лагереның* мөселман хәрби әсирләре газетасы. 1919 елда Берлинда аена 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә, барысы 8 саны чыга. Мөхәррире — Б.Сәйфелмөлеков (Камалетдинов). «Т.и.» татар солдатларының телен, традицияләрен, милли үзаңын саклауга ярдәм итәргә тиеш була. Аеруча актив автор — Вюнсдорф лагере җитәкчеләренең берсе — имам Ә.*Идриси*. Газетада Г.Мостакаев (Биги) шигырьләре басыла. Лагерь тормышы, андагы халык инструментлары оркестры концертлары, спорт ярышлары, дини бәйрәмнәр турында Х.Фәйзи даими язып тора. Берлинда укыган татар студентлары һәм мәктәп укучыларының мәкаләләре урын ала. Татар һәм Урал-Алтай төбәге халыклары тарихына багышланган мәкаләләр дөнья күрә. Матур әдәбият әсәрләре, дин мәсьәләләренә багышланган язмалар басыла. Башка хәрби әсирләр лагерьларында да таратыла. Ватанына китәр алдыннан һәр татар хәрбиенә истәлек өчен газеталар тупланмасы бирелә. Каты тышлыкка төпләнгән (алгы ягында — Вюнсдорф мәчетенең рәсеме, артында — 1920 елга мөселман дини бәйрәмнәре календаре) әлеге тупланмага чыккан саннарның барысы да теркәлгән була.

*Әд.:* Г а р и ф у л л и н Д. «Татар иле» Алман җирендә // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1996. № 1/2.

**ТАТА́Р ИСЛАМЫ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 36 *км* көньяк-көнбатыштарак, Әрә елгасы буенда. 2010 елда 86 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Мәчет.

1647–51 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.И.нда мөселман гыйбадәтханәсе, 3 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 664 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 99 ир-ат; 1859 да — 433, 1897 дә — 704, 1908 дә — 735, 1920 дә — 853, 1926 да — 234, 1938 дә — 228, 1949 да — 187, 1958 дә — 154, 1970 тә — 140, 1979 да — 130, 1989 да — 81, 2002 дә — 97 кеше (1859, 1897, 1908 һәм 1920 еллардагы мәгълүматлар Рус Исламы авылын кертеп бирелә).

**ТАТА́Р КАБАНЫ́** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 37 *км* көньяктарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 66 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — яшелчәчелек. Клуб. 1565–67 еллардан Селик Кабан исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Кабан буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, суган үстерү, кирпеч сугу, мич чыгару, тегү, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, җил тегермәне, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1249 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Әстерхан волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 51, 1859 да — 198 ир-ат; 1897 дә — 728, 1908 дә — 823, 1920 дә — 930, 1926 да — 860, 1938 дә — 676, 1949 да — 408, 1958 дә — 289, 1970 тә — 196, 1979 да — 125, 1989 да — 92, 2002 дә — 82 кеше.

**ТАТА́Р КАДРӘГЕ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 9 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан — Пермь автомобиль юлы буенда. 2010 елда 18 кеше (татарлар) яши. 1565–68 еллардагы рус чыганакларында Ярнушевская Урсекова исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 222,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Арча волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 16 ир-ат; 1859 да — 61, 1897 дә — 96, 1908 дә — 112, 1920 дә — 234, 1926 да — 252 (Рус Кадрәге авылы халкын да кертеп), 1938 дә — 126, 1949 да — 144, 1958 дә — 126, 1970 тә — 80, 1979 да — 50, 1989 да — 36, 2002 дә — 23 кеше.

**ТАТА́Р КАЗЫСЫ́** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 30 *км* көньяктарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 495 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1646 дан рус чыганакларында Атар буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Солтан (Кече Солтан) исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 2 ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1682 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Казиле волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1930 ның 10 августыннан — Питрәч, 1935 нең 10 февраленнән — Балык Бистәсе, 1944 нең 19 февраленнән — Солтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 70 ир-ат; 1859 да — 483, 1897 дә — 891, 1908 дә — 1104, 1920 дә — 1164, 1926 да — 978, 1949 да — 917, 1958 дә — 775, 1970 тә — 794, 1979 да — 704, 1989 да — 532, 2002 дә — 520 кеше.

**ТАТА́Р КАНДЫЗЫ́** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 35 *км* көньяктарак, Кандыз елгасы буенда. 2010 елда 933 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, казлар үстереп сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.К.нда 2 мәчет, мәктәпләр, русча укырга-язарга өйрәтү мәктәпләре, 3 су тегермәне, земство почта станциясе була; шимбә базары, ярминкә (6 декабрьдә) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 6073 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Салих волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1859 да — 1066, 1889 да — 1220, 1897 дә — 1510, 1910 да — 2120, 1920 дә — 2230, 1926 да — 2333, 1938 дә — 1781, 1949 да — 1472, 1958 дә — 1462, 1970 тә — 2078, 1979 да — 1644, 1989 да — 1317, 2002 дә — 1023 кеше.

**ТАТА́Р КАРАМАЛЫСЫ́** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 18 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Карамалы елгасы буенда. 2010 елда 340 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәчет. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Карамалы исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәктәп, ярма яргыч, су тегермәне, ашлык саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3192 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Карамалы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1834 тә — 884, 1870 тә — 1027, 1897 дә — 906, 1920 дә — 1301, 1926 да — 833, 1938 дә — 959, 1949 да — 666, 1958 дә — 645, 1970 тә — 720, 1979 да — 627, 1989 да — 392, 2002 дә — 366 кеше.

**ТАТА́Р КИТАБЫ́ ЦЕНЗУ́РАСЫ**, 1801 елда Казанда *Азия басмаханәсе* ачылу б-н бер үк вакытта кертелә. Мөселман китапларын фәкать үзенең шәхси рөхсәте б-н нәшер иттерүче Оренбург Мөхәммәди дини канун Җыены мөфтие билгеләгән И.И.*Хәлфин* 1801 дән цензор итеп куела. Т.к.ц. 1812 дә Казан ун-ты каршындагы Цензура ком-ты карамагына тапшырыла. 1828 гә кадәр татар китаплары цензоры булып И.И.Хәлфин кала, аннары бу вазифаны татар китапларын бастыруга каршы булмаган шәркыятьче профессорлар: Ф.И.*Эрдман* (1828–45), И.Н.*Березин* (1845–50), А.К.*Казимбәк* (1850–55), И.Ф.*Готвальд* (1855–74) башкара. Диния нәзарәте басылган китаплар өстеннән күзәтү оештыра, күп кенә наширләр һәм басмаханә хуҗалары Коръән һәм традицион мөселман әдәбияты текстларындагы хаталар өчен эзәрлекләнүгә дучар була. Диния нәзарәте күзәтчелеге аркасында Г.Курсави, Г.Утыз-Имәни һ.б. фикер ияләренең язмаларын бастыру мөмкин булмый, алар кулъязма хәлендә тарала.

1874 тә Т.к.ц. С.-Петербург цензура ком-тына тапшырыла, нәшрият һәм басмаханәләрнең цензура үзәгеннән еракта булуы татар әдәбиятын нәшер итү һәм таратуда җитди комачаулыклар тудыра. Ком-тта татар китаплары цензорлары проф.-гарәп теле белгече В.Р.Розен (1874–78), дипломат, гарәп-христиан Ф.Сарруф (1878–80) (икесенең дә татар телен белүләре шикле), үтә реакцион фикерле, рус һәм чит ил әдәбиятының татар теленә тәрҗемәләрен, татар язучылары әсәрләрен, фәнни-популяр әдәбиятны, дини әсәрләрне бастырып таратуга каршы проф.-тюрколог В.Д.Смирнов (1880–1905) була. 1905 кә кадәр татар вакытлы матбугатын нәшер итүгә рөхсәт бирелмәү, нигездә, Смирновның тоткан позициясенә бәйле була. 1905 нең 11 июлендә Матбугат эшләре буенча баш идарә тарафыннан татар вакытлы матбугаты цензурасы Н.И.*Ашмаринга* тапшырыла.

Басылып чыкканга кадәрге цензураны 1905 елның 17 октябрь Манифесты гамәлдән чыгара. 1906 да басылган китаплар һәм вакытлы матбугат өстеннән күзәтчелекне гамәлгә ашыручы *Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитеты* оештырыла. 1914 нең 20 июлендә аңа кабат кертелгән хәрби цензура йөкләнә. Ком-тның эшчәнлеге Вакытлы хөкүмәтнең 1917 ел 27 апрель карары б-н туктатыла, вазифалары Вакытлы хөкүмәтнең губерна комиссарына тапшырыла. Февраль рев-циясеннән соң, чынлыкта, татар китапларына цензура булмый.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; шул ук. Татарская книга пореформенной России. К., 1983; Габдельганеева Г.Г. Полиграфия и печать в Казанской губернии. 1800–1917 гг. К., 2005.

*Г.Г.Габделганиева, Е.В.Липаков.*

**ТАТА́Р КИТА́П СӘҮДӘСЕ́**, Идел буенда 17 йөздән, Европа һәм шәрекъ илләрендә гарәп шрифты б-н китап бастыру башланганнан бирле яшәп килә. 17–18 йөзләрдә читтән китерелгән китаплар, соңрак җирле китаплар б-н дә сәүдә итәләр. Т.к.с. баштан ук китап бастыру б-н параллель рәвештә үсеш ала: наширләр (Г.Бурашев, Апанаевлар, А.Юнысов, Р.Сәгыйтов, Р.Әмирханов һ.б.) бер үк вакытта сату б-н дә шөгыльләнәләр, китаплар татар сәүдә йортларында башка товарлар янәшәсендә сатыла. 19 йөз башына кадәр китаплар, нигездә, Госманлы империясеннән сатып алына. Бигрәк тә Коръән һәм аның тәфсирләре үтемле була. Казанда басылган беренче китаплар булып «Әттәхият» (иҗекләп уку) әлифбасы һәм Коръәннән сүрә һәм өземтәләр тупланмасы «Һәфтияк» санала. 19 йөзнең 2 нче яртысына кадәр татар китап базары ярлы була; реформа чорында татар дөньяви әдәбияты үсеш алу б-н, аның тизләтелгән үсеше өчен шартлар барлыкка килә. 1865 елда «Цензура турында вакытлыча кагыйдәләр» кертелү сәбәпле, вазгыять катлауланa: шәрекъ телләрендәге китаплар б-н сату итү өчен махсус таныкнамә рәсмиләштерергә кирәк була (1866 да аны беренчеләрдән булып наширләр М.Салихов һәм Ф.Амашев ала). 1877 дә Казанда китап б-н сәүдә итә торган — 5, 1881 дә — 15, 1886 да — 12, 1891 дә 7 татар сәүдә йорты була. Китап кибетләре саны кимү сәүдәнең эре эшмәкәрләр (Ш.Хөсәенов, *Кәримовлар*, И.Идрисов, Әхмәдуллиннар һ.б.) кулына күчүе б-н аңлатыла. Алар 20 йөз башында бер үк вакытта наширлек һәм сәүдә б-н шөгыльләнүче китап ширкәтләре оештыралар.

Казан китап ширкәтләренең Идел һәм Урал буе шәһәрләрендә ф-ллары була: бертуган Кәримовларның — Уфада, Оренбургта, Сарапулда, «Идрисов, Галиев һәм К°» ның — Уфада, Минзәләдә, Әстерханда, «Сабах»ның — Уфада, М.Г.Мусинның — Троицкида, «Хөсәенов варислары»ның — Уфада, Ш.К.Шаһидуллинның — Оренбургта һ.б. Китап сәүдәсе Түбән Новгород, Әрбет һәм Минзәлә ярминкәләрендә актив бара, монда мөселман китаплары 19 йөзнең 1 яртысыннан бирле сатыла. 1915 тә Түбән Новгород ярминкәсендә татар һәм башка шәрекъ телләрендәге әдәбият б-н сәүдә капиталы әйләнеше якынча 80 мең сум тәшкил итә. Кәримовлар, «Хөсәенов варислары», «Гасыр», «Мәгариф», «Сабах», «Васита», «Юл», М.Г.Кадыйров, А.Үтәгәнов, Ибраһимов һ.б. ширкәтләре сәүдәне 1920 еллар ахырына кадәр дәвам итә.

19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башында, нигездә, Казан басмаханәләрендә басылган китаплар сатыла (татарлар һәм империянең башка халыклары, ш.у. казакъ, башкорт һ.б. төрки халыклар өчен дә). 19 йөз ахыры — 20 йөз башында сәүдә йортлары үз ассортиментының басма каталогларын чыгара (к. «*Әсәми көтеб*»). Җирле басмалардан кала, татар китабы сәүдәгәрләре шәрекъ илләре китапларын сатуны да дәвам итә (алар Казанга Одесса һәм Әстерхан таможнялары аркылы килә). Сәүдә үсеше б-н бәйле рәвештә, китап сатучылар әдәбиятны Иран, Төркия, Мисыр, Иордания, Сүрия, Ливия, Һиндстандагы эре нәшрият үзәкләренә агентлар аша заказ биреп кайтарта. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында Казан сәүдә йортларында хокук фәннәре, теология, фәлсәфә, мантыйк, табигыять белеме, математика, тел белеме, мед. буенча чит илләрдән алынган дәреслек-кулланмалар, фәнни, популяр һәм белешмә китаплар; гарәп, фарсы һәм төрек телләрендәге матур әдәбият әсәрләре сатыла.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; Габдельганеева Г.Г. Книжная торговля в Казанской губернии: вторая половина XVIII в. — 1917 г. К., 2006.

**«ТАТА́Р КИТАПЛАРЫ́»**, библиографик күрсәткеч. ТР Китап палатасы (2007 дән — ТР Дәүләт матбугат архивы) тарафыннан нәшер ителә. 1 нче томда (1979) үз эченә 1917 елның ноябреннән алып 1929 га кадәрге чорда нәшер ителгән татар китаплары, брошюралар, ноталар, 2 нче томда (1986) — 1930–40 та ТАССР һәм СССР шәһәрләрендә нәшер ителгән басмалар, 3 нче томда (1995) — ТАССРда 1918–1940 та нәшер ителгән русча китаплар, 4 нче томда (1995) — 1941–60 та нәшер ителгән татар китаплары, брошюралар, ноталар, 5 нче томда (2004) — 1961–80 дә нәшер ителгән татар китаплары, брошюралар, ноталар, 6 нчы томда (2010) — 1981–2000 дә нәшер ителгән татар китаплары, брошюралар, ноталар тасвирламасы бирелә. Бүлекләр: марксизм-ленинизм, филос., икътисад, тарих, хокук, табигыять белеме, а.х., мед. фәне, филол. фәне, сәнәгать, транспорт, элемтә, мәдәният (ш.и. матур әдәбият һәм сәнгать), мәгариф, дин, матбугат, гомуми характердагы белешмәлекләр, энциклопедияләр һ.б. 5 нче томга сукырлар өчен чыгарылган әдәбият кертелгән. Бүлекләр эчендә китаплар исемлеге алфавит тәртибендә бирелгән автор фамилияләре яки китап исемнәре буенча урнаштырылган. Томнар ахырында исемнәр күрсәткече, китап исемнәре, топографик (нәшер ителү урыны) ярдәмче күрсәткечләр бирелә. Библиография төзү өчен ТР Китап палатасы, Казан ун-тының Фәнни китапханәсе, Татарстанның һәм Башкортстанның респ-ка китапханәләре фондлары һәм каталоглары, Бөтенсоюз (хәзерге Россия) китап палатасының еллык басмалары, елъязмалары, нәшриятларның планнары һәм хисаплары файдаланыла.


**ТАТА́Р КОКШАНЫ́** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 29 *км* төньяктарак, Удмурт Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 61 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Китапханә. 1850 елларда морза Ямбулатовлар биләмәсендә нигез салына. Халкы игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1876 ның башында Т.К.нда мәчет (архит-ра истәлеге) төзелә. 19 йөз ахырында авыл җәмгатенең имана җире 776,3 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1879 да — 36, 1920 дә — 149, 1926 да — 173, 1938 дә — 216, 1949 да — 198, 1958 дә — 161, 1970 тә — 121, 1979 да — 106, 1989 да — 70, 2002 дә — 61 кеше.

**ТАТА́Р КОММУНИСТЛА́Р УНИВЕРСИТЕТЫ́** (ТКУ), 1922 елда РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты пленумы карары нигезендә, иҗтимагый фәннәр укытучылары, беренче башлап ТАССР өчен, 1925 тән — барлык Идел буе респ-калары, 1930 дан ТАССР һәм татарлар тупланып яшәгән башка төбәкләр өчен партия һәм совет хезмәткәр кадрлары әзерләү максаты б-н ачыла. ВКП(б) өлкә ком-ты карамагында була. Студентларның 50% тан 65% ка кадәрен татарлар тәшкил итә, ләкин татар телендә укыту 1928 дә генә башлана. Т.к.у.на партия органнары тәкъдиме буенча башлангыч белем б-н, җәмәгать эшендә тәҗрибәсе булган һәм кабул итү сынауларын узган коммунистлар һәм комсомоллар кабул ителә. Укыту планы, нигездә, гомуми белем бирү (тарих, география, математика, табигать белеме, рус, татар һәм немец телләре, татар тел белеме, ораторлык сәнгате) һәм идеологик фәннәрдән (марксизм-ленинизм, тарихи материализм, политэкономия) тора, җитәкчелек эшенә әзерләүче махсус курслар булмый. Җәй көне студентлар өчен практика оештырыла (ТАССР р-ннарында агитация эше). Уку вакыты 3 ел. Укытучылар арасында — Ф.К.Сәйфи-Казанлы, Г.С.Гобәйдуллин, С.П.Сингалевич. Ел саен 50–60 кеше тәмамлый (өлгермәгән, тәртип бозган өчен һәм идеологик сәбәпләр б-н студентларның яртысы диярлек укудан чыгарыла); тәмамлаучыларның күбесе партия һәм совет органнарына ВКП(б)ның район ком-тлары секретарьлары, бүлек мөдирләре, совет органнарының җаваплы хезмәткәрләре, пр-тие җитәкчеләре итеп җибәрелә, калганнары укытучы һәм пропагандист була, яхшы укучылар укуларын аспирантурада һәм Кызыл профессура ин-тында дәвам итә. 1925 тән икееллык аспирантура эшли (диссертация яклау каралмаган). Башта анда — 5–10, 1930 да 20 кеше укый; тәмамлаучыларны югары уку йортларында идеологик фәннәр укытырга җибәрәләр. Т.к.у. каршында партия һәм совет хезмәткәрләре өчен кичке һәм читтән торып уку бүлекләре, квалификация күтәрү курслары эшли. ВКП(б) ҮКның 1932 ел 21 сентябрь карары нигезендә барлык коммунистлар ун-тлары, ш.и. Т.к.у.да, югары а.х. коммунистлар мәктәбе итеп үзгәртелә; ике бүлеге эшли: икееллыгы колхоз, совхоз һәм МТС җитәкчеләрен әзерли, өчьеллыгын тәмамлаучылар авыл районнарының партия һәм совет органнарына эшкә җибәрелә. Югары мәктәпләр программасына а.х., техник, икътисади һәм идеологик фәннәр керә; шуңа карамастан, уку йорты Т.к.у. дип аталуын дәвам итә. 1941 дә ябыла.

*Әд.:* X лет ТКУ. К., 1932.

**ТАТА́Р КӨ́НЧЫГЫШ МУ́ЗЫКА МӘКТӘБЕ́**, 1918–22 елларда Оренбург шәһәрендә ачыла. Аның эшенең төп максаты — татар һәм башкортлардан җырчылар һәм музыкантлар әзерләү. Укучылар һәм укытучылар

КАЗАН ГУБЕРНАСЫ КРӘСТИЯННӘРЕНЕҢ 1878 елгы КУЗГАЛЫШЛАРЫ




арасында — булачак композиторлар С.Җ.Сәйдәшев, М.М.Вәлиев, музыка белгече Х.И.Булатова-Терегулова.

**ТАТА́Р КРӘСТИЯННӘРЕ́ КУЗГАЛЫШЛАРЫ́**, 1878–79 елларда социаль-икътисади, милли изүне көчәйтүгә каршы Казан губернасының Казан, Мамадыш, Спас, Тәтеш һәм Чистай өязләрендәге крәстияннәр чыгышлары. 1878 нең октябрендә Казан губернасының крәстиян эшләре кабулханәсе тарафыннан нәшер ителгән халык җыемнары һәм йөкләмәләре турындагы инструкцияне халыкка җиткерү сәбәп була. Инструкциядә янгынга каршы көрәш һәм җиһазлары б-н янгын сарайлары оештыру, корылмаларны мәҗбүри рәвештә иминиятләштерүгә һәм урядниклар, стражниклар, писарьлар, старшиналар тотуга җыемнар, «Илаһи канун» укытуны кертү, нинди диндә булуларына карамастан, һәр авыл җәмәгатенең чиркәүләрне һәм чиркәү-приход мәктәпләрен үз хисапларына тотарга тиешлеге карала. Татарлар инструкцияне көчләп христианлаштыруның яңа этабы буларак кабул итә. Мораса волостеның Иске Үргәгәр һәм Татар Мулла иле, Спас өязе Полянка волостеның Зур, Урта һәм Түбән Тигәнәле, Лягушкино, Мордва Болагы һәм Тигән-Буләк авыллары крәстияннәре хакимияткә көчле каршылык күрсәтә. Күтәрелгән крәстияннәрне Ш.Габделхәкимов, Х.Миндубаев, Г.Манюров, А.Сәйфетдинов, М.Габделхәкимов, А.Хөсәенов, Х.Исхаков һ.б. җитәкли. Крәстияннәр үз корылмаларын иминиятләштерүдән, янгын сарайларын тәэмин итүдән, башка йөкләмәләрне үтәүдән баш тарталар, җирле хакимият вәкилләрен авылларга кертмиләр, авыл старосталарының мөһерләрен тартып алалар, аларга җирле хакимиятләрнең күрсәтмәләрен кабул итүне тыялар, ә кайбер авылларда авыл старосталарын алыштыралар. Крәстияннәр хәрәкәте 1878 нең ноябрь ахырында Казан өязендә аеруча киң колач җәя. Чуалышларда 40 тан артык авыл катнаша. Инструкцияне аңлап кайтырга Олы Мәңгәр волостендә крәстияннәре вәкилләрен волость идарәсенә, өяз исправнигына һәм губернаторга җибәрәләр. Хакимиятләрнең крәстияннәрне тынычландыру омтылышлары уңышсыз була. 26 ноябрьдә 12 авылның ирләре Олы Мәңгәрдә урнашкан волость идарәсенә килә. Икенче көнне, бу авылларның старосталарын вазифаларыннан азат итеп, алар урынына үз кешеләрен билгеләп, волостьның яңа старшинасын һәм писарен сайлыйлар. 28–29 ноябрьдә Олы Әтнә һәм Мәмсә волостьлары крәстияннәре, волость үзәкләрендә җыелып, урындагы кешеләрне кыйныйлар, канцелярияне тузгыталар (Олы Әтнә вол.), волость идарәчеләрен һәм старостасын яңадан сайлыйлар. Крәстияннәр кузгалышы ш.у. Казан өязенең Арча, Балтач һәм Яңа Кишет волостьларында да була. 1878 нең ноябрь–декабрендә Чистай өязенең Биләр, Красный Яр, Краснар, Мөслим волостьларына җәелә. Мамадыш һәм өлешчә Тәтеш өязләре крәстияннәре дәүләт йөкләмәләрен үтәүдән баш тарталар, вазифалы затларны урыннарыннан алалар. Кузгалышлар булган районнарга хакимиятләр хәрби частьлар җибәрә. Казан өязендәге крәстияннәр кузгалышы декабрь башында килеп җиткән губернатор Н.Я.Скарятин җитәкчелегендәге солдатлар батальоны тарафыннан аяусыз бастырыла. Олы Мәңгәр волостенда – 800 гә кадәр, Олы Әтнәдә – 400 гә кадәр, Мәмсәдә 800 гә кадәр кеше тән җәзасына дучар ителә. Мәмсә авылының 3 крәстияне – каторга эшләренә, 4 се – Себергә, 2 се арестант роталарына хөкем ителә.

1879 да Казан губернасында крәстияннәр кузгалышы кабатлана: гыйнварда Мамадыш өязе Көек авылы крәстияннәре күтәрелә (крәстияннәрнең салым җыючы сайлау турындагы карарын волость идарәсенең татар теленнән рус теленә күчерү таләбе сәбәп була); 1879 ның февралендә Спас өязе Түбән Үргәгәр крәстияннәре полиция һәм янгынга каршы старосталар сайлаудан баш тарталар. Спас өязе Тигәнәле авылы крәстияннәре дә хакимиятләргә каршылык күрсәтүне дәвам итә, ел буе крәстияннәр үзидарәсе хөкем сөрә. Крәстияннәр авылга хакимият вәкилләрен кертмиләр, боерыкларын үтәмиләр, салымнар түләүне туктаталар. Аларга Спас өязенең Зур, Урта, Түбән Тигәнәле, Гаделша авыллары крәстияннәре дә иярә. Крәстияннәр кузгалышы Казан губернасының башка өязләрендә дә күзәтелә. 1880 еллар башында чуалышлар аяусыз рәвештә бастырыла.

*Әд.:* Смыков Ю.И. Крестьяне Среднего Поволжья в борьбе за землю и волю. К., 1973.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ТАТА́Р КУЛЪЯЗМА́ КИТАБЫ́**. Ислам дине кабул итү чорыннан (10 йөз башы) бирле билгеле, сакланып калган китаплар арасыннан элгәреләре 11 йөзгә карый. Басма китапларның кыйммәт булуы һәм цензура киртәләре аркасында кулъязма китаплар традициясе татарларда 20 йөз башына кадәр яши. Мондый китапларның бер өлеше — гарәп һәм фарсы телләрендә, күп кенә кулъязмалар ике яки өч телдә язылган. Китапларның күбесе мөселман дине эшлеклеләре һәм мәдрәсәдә уку чорында шәкертләр тарафыннан күчерелгән. 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башында һәр авыл мулласының берничә дистә кулъязма китаптан торган китапханәсе булган. Күчереп язучылар һәм китап хуҗалары арасында сәүдәгәрләр, шәһәр кешеләре һәм крәстияннәр дә бар. Күп кенә кулъязмалар *каллиграфия* сәнгате истәлекләре булып тора (к. *Мәхмүдов Мөхәммәтгали, Әхмәтҗан бине Габдерәхим әл-Болгари, Габденнасыйр бине Сабит бине Сәфәргали әл-Әчкени, Габәш, Габдулла бине Кәлимулла әл-Болгари*). 18 йөздә бигрәк тә Коръән, «Һәфтияк» (Коръәннең кыскача аңлатмасы), дини тәгълимат һәм мөселман хокукы буенча фундаменталь хезмәтләр (соңрак аларны басмаханәләрдә баса башлыйлар) күчереп языла. 19 йөздә шул чор татар дин белгечләре һәм фикер ияләренең (Г.Курсави, Г.Утыз-Имәни, Т.Ялчыгол, Ш.Мәрҗани һ.б.) кулъязмалары, тарихи хезмәтләр, Оренбург Мөселман Диния нәзарәте тарафыннан хупланмаган һәм дәүләт цензурасын үтмәгән әдәби әсәрләр (Мәүлә Колый, Ә.Каргалый, М.Акмулла, Г.Кандалый, Һ.Салихов, Г.Чокрый, Ш.Зәки һ.б.) киң таралыш ала. Казанда (ун-тта һәм руханилар академиясендә), С.-Петербургта (Азия музеенда һәм ун-тның Шәрекъ ф-тында) һәм Мәскәүдә (Лазарев ин-тында, Румянцев китапханәсендә) татар кулъязма китапларыннан торган тупланмалар барлыкка килә. Совет чорында дәүләт коллекцияләре репрессияләнгән мәдәният эшлеклеләреннән конфискацияләнгән һәм Ш.Мәрҗани, Г.Баруди, И.Динмөхәммәтов, М.Түнтәри һ.б. китапханәләреннән, мәчетләр каршындагы китапханәләрдән ирекле рәвештә тапшырылган китаплар б-н баетыла. ТАССРда мәчетләр һәм шәхси тупланмалардагы кулъязма китапларның күп өлеше дингә каршы көрәш барышында юк ителә. Археограф С.Г.*Вахиди*, 3 меңнән артык башка төрле кулъязма һәм китапларны җыеп, ТАССРның Дәүләт музеена тапшыра. 1963 тән һәр елны М.Г.*Госманов* башлангычы б-н (1988 гә кадәр аның җитәкчелегендә) Казан ун-тының (2000 нән – ТР Милли китапханәсе б-н берлектә) Татарстан, Идел буе һәм Уралның башка төбәкләренә археол. экспедицияләр оештырыла. Экспедицияләр барышында зур кыйммәткә ия Т.к.к.лары табыла. Мондый китапларны саклау урыннарының иң эреләрен Казан ун-тының Фәнни китапханәсе (13 меңнән артык китап), ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты (7 меңнән артык), ТР Милли китапханәсе (3 меңгә якын), ТР Милли музее (200 гә якын), ТР Милли архивы (250 гә якын, Казан руханилар академиясе тупланмасы) тәшкил итә. Татарстаннан читтәге аеруча мөһим тупланмалар РФАнең Шәрекъ кулъязмалары ин-тында (С.-Петербург, 400 гә якын), Россия дәүләт китапханәсендә (Мәскәү, 1 меңгә якын), РФА Урал фәнни үзәгенең Тарих, тел һәм әдәбият ин-тында (Уфа ш., 2,5 меңнән артык), БР Милли музеенда (200), БР Милли китапханәсендә (200 гә якын) саклана. Т.к.к.н өйрәнү үзәге булып ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының кулъязмалар бүлеге, Казан ун-ты Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, ТР Милли китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге тора. Кулъязма китапларны өйрәнү нигезендә Кол Гали, Кол Шәриф, Мәүлә Колый һ.б.ның әсәрләр җыентыклары, татар әдәбияты һәм иҗтимагый фикер ядкәрләре дөнья күрде.

Чыг.: Халидов А.Б. Каталог арабских рукописей Института народов Азии Академии наук СССР. М., 1960. Вып. 1; Гилязутдинов С.М. Описание рукописей на персидском языке из хранилища Института языка, литературы и искусства: В 3 вып. К., 2002–07; Дмитриева Л.В. Каталог тюркских рукописей Института востоковедения Российской академии наук. М., 2002; Арсланова А.А. Описание рукописей на персидском языке Научной библиотеки им. Н.И.Лобачевского Казанского государственного университета. М.–К., 2005.

*Әд.:* Әхмәтҗанов М.И. Татар кулъязма китабы. К., 2000.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ТАТА́Р КУРЧА́К ТЕА́ТРЫ «ӘКИЯ́Т»**, дәүләт карамагында. 1998 елга кадәр Казан курчак театры, 1998 дән хәзерге исемендә. 1932 дә Үзәк пионерлар клубы каршында үзешчән курчак театры буларак оеша. Сәнгать җитәкчесе — М.З.Райская, пед. бүлек мөдире — Е.С.Рухлядева, рәссам С.Федотов була. Труппа составында — курчак уйнатучы артистлар Золотарёва, И.Матвеев, Е.Сергеева, Н.Смелков, Г.Славуцкий, В.Устинова. 1934 тә рус һәм татар төркемнәре булган Беренче дәүләт интернациональ курчак театрына үзгәртелә (директоры һәм сәнгать җитәкчесе — С.М.Мерзляков). Элекке составның кайбер актёрлары б-н берләштән труппага С.Вәлиуллина, П.Бикмөхәммәдова, Б.Рычков, В.Гафаров, М.Хисамова, Ф.Таһиров, Р.Хәбибуллина, М.Язвина, Х.Сабитова, Г.Медведев керә. 1941 гә кадәр күчмә театр буларак эшли, 1941 дә Казан яшь тамашачылар театрында (ТЮЗ) стационар җирлеккә ия була, анда фойе залларының берсендә, кайвакыт төп сәхнәдә тамашалар күрсәтә. 1959 дан 2012 гә кадәр элекке Изге Рухның җиргә төшүе чиркәве бинасында эшли, 2012 дән яңа бинага (арх. С.Ә.Мәмлиева) күчә.

1932–41 дә актёрлар, нигездә, кулга киеп уйный торган (перчаткалы) курчаклар б-н эш итәләр; эшче яшьләр театрлары (к. *ТРАМ*), ш.у. публицистик һәм дидактик юнәлешле һәм социаль әчтәлекле «тере газета» алымнарыннан файдаланучы халык курчак «Петрушка театры» традицияләренә нигезләнгән тамашалар күрсәтелә. Репертуарын «Юлдан язган Петрушка» («Петрушка-беспризорник»), «Чит илдән килгән Петрушка» («Петрушка-иностранец») һ.б. спектакльләре тәшкил итә, аларның күбесе С.М.Мерзляков тарафыннан иҗат ителә. Шулай да бу чорда ук инде театр матур әдәбиятка, әкият инсценировкаларына нигезләнгән сәхнә әсәрләре исәбенә репертуарны төрләндерергә омтыла: «Бертуган Монгольфьелар» («Братья Монгольфье», Г.Л.Владычина һәм Е.Тараховская), «Каштанка» (Е.В.Сперанский, А.П.Чехов хикәяләре буенча), «Каз бәпкәсе» («Гусёнок», Н.В.Гернет), «Шат күңелле тегүче» («Весёлый портняжка», С.Веприцкая; бертуган Гриммнар әкияте буенча), «Канатлы ат» («Конёк-Горбунок», П.П.Ершов), А.С.Пушкин әкиятләре һ.б. Алар театрның әчтәлеген һәм сәнгатьчә сурәтләү чараларын баетуга булышлык итәләр. Репертуарда Г.Тукайның «Кәҗә белән Сарык», «Шүрәле» әкиятләренә нигезләнеп иҗат ителгән



Татар курчак театры «Әкият».

һәм милли репертуарга нигез салган спектакльләр аерым урын алып тора. 1937 дә Мәскәүдә узган 1 нче Бөтенсоюз СССР курчак театрлары смотрында Казан курчак театрының С.М.Мерзляков тарафыннан рус халык әкиятенә нигезләнеп язылган һәм, татарчага тәрҗемә ителеп, автор версиясе буенча куелган «Өч дус» спектакле билгеләп үтелә. 1940–65 тә Казан курчак театрының сәнгать җитәкчесе С.М.*Хөсни* була. Аның эшчәнлеге театрны торгызуда әһәмиятле роль уйный. Кырыс сугыш елларын кичереп, ирләр составының күпчелек өлешен югалтып, театр күбесенчә зур булмаган бригадалар б-н госпитальләрдә һәм эвакуация пунктларында хезмәт куя («Сугышчан Петрушка» («Воюющий Петрушка»), «Түбәдәге Петрушка» («Петрушка на крыше»); «Кечкенә партизаннар», Ш.Зәйни; «Партизаннар иле турында әкият», Х.Садри; «Камыр батыр», С.Хөсни, Р.Хәбибуллина). 1944–45 тә труппа М.Рычкова, Г.Таһирова, В.Третьякова, Н.Мөбарәкова, Д.Вишневская, Н.Кириллов, И.Трофимов кебек яңа актёрлар б-н тулылана. ТРАМ эстетикасы йогынтысыннан арынып, С.Хөсни коллектив б-н бергә таяклы курчакларны үзләштерә башлый, алар курчак спектакленең сәнгати мөмкинлекләрен шактый киңәйтә, зур стационар спектакльләр иҗат итү мөмкинлеге тудыра. С.М.Хөснинең рәссамнар Э.Б.Гельмс һәм П.П.Троицкий б-н бергә куйган «Хуҗа Насретдин», «Әбүгалисина» (Н.Исәнбәт пьесалары буенча), «Галәветдиннең тылсымлы лампасы» («Волшебная лампа Аладдина», Н.В.Гернет





Татар курчак театры «Әкият» спектакльләреннән күренешләр: 1. «Апушның тылсымлы төшләре», Р. Бохараев. 1986; 2. «Камыр батыр», С. Хөсни. 2002.

пьесасы буенча), «Башмаклар» («Черевички», Н.В.Гогольнең «Раштуага каршы төн» — «Ночь перед Рождеством» повесте буенча) спектакльләре Казан курчак театры тарихында зур вакыйга буларак кабул ителә һәм аның киләчәктәге сәнгати үсеш дәрәҗәсен билгели. «Айтуган» (Ш.Зәйни), «Кисекбаш» (Ә.Камал), «Тапкыр егет» (Д.Аппакова), «Алпамша», «Хәйләкәр Тажи» (С.Хөсни), «Мияубикә йорты» («Кошкин дом», С.Я.Маршак), «Кар патшабикәсе» («Снежная королева», Е.Л.Шварц) әсәрләре буенча куелган спектакльләр дә театрның зур эшләреннән санала.

1965–68 дә театрга И.М.Москалёв режиссёр булып килә. «Тере план»дагы актёрлар б-н курчак уйнату техникасының барлык төрләрен дә үзара берләштергән курчак тамашаларының принципиаль яңа эстетикасын үзләштерү өлкәсендә «Кыю әкият» («Смелая сказка», А.П.Гайдар әсәрләре буенча), «Кечкенә принц» («Маленький принц», А. де Сент-Экзюпери повесте буенча) спектакльләре театрның зур казанышы була. Натурализмнан катгый рәвештә баш тартып, курчакларның аеруча матур һәм тәэсирле күренешенә омтылып, образ бөтенлегенә, курчак тамашаларының жанр төрлелегенә ирешеп, театр бу чорда төп игътибарны уйнаучы курчаклар театры сәнгате үзенчәлекләрен ачуга юнәлтә. Труппа В.Гыйбадуллина, А.Хөснетдинов, М.Әпсәләмов, Г.Вишняков, В.Маякова, Н.Шестопалова, Л.Дьяченко, И.Зиннуров, З.Алексеева кебек актёрлар б-н тулылана. Театр б-н хезмәттәшлек итүгә Р.Батулла, Т.Миңнуллин, Л.Ихсанова, Н.Фәттах, Ю.Адаш, Г.Сабитов, Н.Дәүли, Р.Бохараев, Л.А.Кожевников, Р.Харис, Г.Зәйнашева, Ф.Тарханова, Аманулла, Р.Зәйдулла, Р.Мөхәммәтшин, Ә.Мушинский, М.Гыйләҗев, З.Хөснияр, Зөлфәт, А.Хәиров кебек авторлар актив рәвештә җәлеп ителә. Аларның пьесалары 1970–90 еллар репертуарын тәшкил итә. Театр репертуарында чит ил драматургларының пьесалары да шактый урын ала, алар театр сәнгатен дөнья халыклары курчак театрларының уен алымнары б-н баета. Бу чор спектакльләрендә әйдәп баручы рольне рәссам үти, ул А.А. һәм В.Е.Губскийлар бизәгән спектакльләрдә аеруча ачык күренә: «Ана күзләре» (И.Зиннуров), «Энҗеле Үрдәк» (Н.Фәттах), «Елан күзе» (И.Зиннуров), «Йөнтәс тылсымчы» («Пушок-волшебник», А.Попеску), «Винни-Пух һәм башкалар» («Винни-Пух и все-все-все», А.Милн), «Апушның тылсымлы төшләре» («Волшебные сны Апуша», Р.Бохараев), «Золушка» (Ш.Перро). Театрның бу еллар репертуары өлкәннәр өчен куелган спектакльләр б-н дә тулылана: «Гасырдан да озын көн» («И дольше века длится день», Ч.Айтматов повесте буенча), «Чегәннәр» («Цыганы», А.С.Пушкин поэмасы буенча), «Паппет шоу» эстрада тамашасы (Л.А.Дьяченко), «Назлы йөрәк бәлаләре» («Беда от нежного сердца», В.А.Соллогуб) водевиле, «Диләфрүзгә дүрт кияү» (Т.Миңнуллин) комедиясе. 1974 тән театр — халыкара УНИМА курчак театрлары оешмасының коллектив әгъзасы; 2005 тән – «Курчак театры–XXI гасыр» Россия ассоциациясе әгъзасы; 2009 дан Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исем. бүләге лауреаты; халыкара УНИМА фестивальләре, симпозиумнары һәм конгрессларында катнашу максаты б-н, Венгрия, Польша, Югославия, Болгария, Төркия, Германия, Франция, АКШка бара. Театр Россиядә дә, аннан читтәге шәһәрләрдә дә актив рәвештә гастрольләр б-н йөри. Театр куйган спектакльләр — Брауншвейг (ГФР, 1994, «Паппет-шоу», Л.А.Дьяченко), Адан, Измир (Төркия, 1995, «Ат өреккән шомлы төн», Зөлфәт; «Уймак кыз» («Дюймовочка»), Һ.Х.Андерсен, 1999), Канн (Франция, 2000, «Бардым күлгә, салдым кармак», Р.Корбан; «Казлар-аккошлар» («Гуси-лебеди»), Л.А.Кожевников) һ.б. шәһәрләрдә узган халыкара фестивальләр дипломантлары. 2013 тә Казанда курчак театрларының 1 нче халыкара «Шомбай-fest» фестивале уза. Театр фестивальне татар халык әкиятләренә нигезләнгән «Өч кыз» («Три дочери», А.Хәиров) спектакле б-н ачып җибәрә. Комп. Ю.Чаплин, хореограф Г.Маннапова һәм актриса Н.Егорова дипломнар б-н бүләкләнәләр. Театр ТР Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләге лауреаты («Иң яхшы курчак театры артисты» номинациясендә — Д.Хуҗиәхмәтов, 2016). Милли үзенчәлекләрне сәхнәләштергән өчен, театр коллективы ТР Президенты каршындагы мәдәниятне үстерү фондының махсус бүләгенә лаек була.



Татар курчак театры «Әкият» спектакленнән күренеш. «Казан турында риваять», М. Гыйләҗев. 2003.

2016 да «Шомбай-fest» икенче тапкыр үткәрелә. Театр фестивальне зурлар өчен «Ханума» (А.Цагарели) спектакле б-н ачып җибәрә. Реж. И.Зиннуров «Иң яхшы режиссёр эше өчен», Г.Маннапова «Хореография өчен» һәм актриса Н.Егорова «Иң яхшы актёр эше өчен» дипломнар б-н бүләкләнәләр. Фестивальдә катнашу өчен, Брест, Витебск (Беларусь), Ашхабад (Төрекмәнстан), Нерюнгри (Саха Респ-касы), Екатеринбург, Белгород һ.б. курчак театрлары килә.

2012 дән театрда музей эшли. Анда 300 дән артык экспонат урнаштырылган.

Театр С.Садыйкова, Х.Вәлиуллин, Ф.Әхмәтов, Р.Ахиярова, Л.Любовский, Р.Кәлимуллин, Л.Батыр-Болгари, Б.Трубин, Ш.Шәрифуллин, М.Шәмсетдинова, А.Хөсәенов, С.Зорюкова, И.Сафин, Ю.Чаплин кебек талантлы композиторлар б-н элемтәдә тора.

Театр репертуарында 40 тан артык спектакль бар. Соңгы елларда театр сәхнәсендә «Камыр батыр» (С.Хөсни), «Су анасы» (Г.Тукай әсәре буенча), «Кәкрүшкә» (Р.Харис), «Щелкунчик» (Э.Т.А.Гофман), «Буратино» (А.Толстой), «Колобок» (В.Фечин), «Жырлап узган җәй» (Н.Дәүли), «Өч кыз» (А.Хәиров), «Кәҗә белән Сарык» (Г.Тукай әсәре буенча), зурлар өчен «Ханума» (А.Цагарели) һ.б. спектакльләр зур уңыш б-н бара.

2016 да театр труппасында — ТРның халык артистлары Р.Фәйзуллина, Н.Егорова, А.Карпеев, Э.Гыйлемханова; ТРның атказ. артистлары Г.Габдрахманова, Р.Гыйздәтуллин, С.Кузнецов, Ф.Сабирова, Д.Үтәшев, В.Фечин, Ю.Чуктиев; актёрлар Ю.Василишина, М.Гайфуллин, Р.Зарипова, Е.Кладова, Л.Нәҗипова, Т.Сорокина, Р.Таһиров, А.Хайсарова, Д.Хуҗәхмәтов, Г.Гаязетдинова, А.Гыймаев, М.Фәйзрахманова, Е.Макарова, Ә.Рамазанова һ.б. Театрның баш режиссёры — РФ һәм ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе И.Н.*Зиннуров* (1977 дән), директоры — РФ һәм ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре Р.С.*Яппарова* (1993 тән).

*Әд.:* Игламов Р.М. Искусство играющих кукол. К., 2004.

**ТАТА́Р МАКЫЛЫ́** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 27 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 166 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре

терлек асрау. Китапханә. Мәчет. 1647–52 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, йөреп сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.М.нда мәчет, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 442 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Келәнче волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 45 ир-ат; 1859 да — 110, 1897 дә — 177, 1908 дә — 265, 1920 дә — 221, 1926 да — 281, 1938 дә — 359, 1949 да — 328, 1958 дә — 286, 1970 тә — 277, 1979 да — 318, 1989 да — 184, 2002 дә — 171 кеше.

**ТАТА́Р МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕГЕ́**, 18–19 йөзләрдә татар җәмгыятендә иҗтимагый-сәяси агым. Аның нигезендә җәмгыять үсешендә аңның хәлиткеч роле турында идеалистик күзаллау, җәмгыятьтәге кимчелекләрне халыкның наданлыгы, үз табигатьләрен белмәве б-н аңлату ята. Рус мәгърифәтчелегендәге кебек үк, Т.м.нә дә патриархаль нигезләрне, дини һәм әхлакый катып калганлыкны, схоластика, хорафатларны тәнкыйтьләү; табигатькә һәм җәмгыятькә рациональ мөнәсәбәт хас. Т.м. 18 йөзнең 2 нче яртысында, социаль-икътисади үзгәрешләр һәм татар халкы арасында башланган чуалышлар (*Батырша хәрәкәте, Батырша хаты*) татар җәмгыятендәге патриархаль нигезләргә реформа кирәклеген, татар халкының белемен һәм мәдәниятен күтәрү зарурлыгын аңлауга китергәннән соң туа. *Батырша*, Г.*Курсави*, Г.*Утыз Имәни*, Х.*Фәезханов*, Ш.*Мәрҗани* һ.б. татарлар арасында мәгърифәтчелек хәрәкәтен башлап җибәрүчеләрдән булдылар. Татар җәмгыятен үзгәртеп коруга омтылган Т.м. идеологлары дөньяга караш принципларының төп юнәлешләрен эшләүдә фикер каршылыгына киләләр. Мәгърифәтчеләрнең кайберләре (*Морад*, Г.*Утыз Имәни*, Б.*Вәисев*) татар җәмгыятен реформалау концепциясен социаль утопия рәвешендә куя, икенчеләре (Г.Курсави) шул чорда яшәп килгән иске карашларга һәм соңгы мөселман традицияләренә (*тәкълид*) иярүчеләргә *иҗтиһад* принципларын каршы куеп (Коръән һәм Сөннә нигезендә дин һәм иҗтимагый тормыш мәсьәләләрендә үз фикереңне әйтү хокукы), мөселман дине кагыйдәләренә реформа ясарга тәкъдим итә, өченчеләр (Ш.Мәрҗани, К.*Насыйри*, Г.*Баруди*, Р.*Фәхретдин*) фәнгә һәм алдынгы мәдәниятка татар җәмгыятенең киң даирәсен тарту зарур дип саный. Т.м. идеологиясе тарафдарлары, нигездә, туып килүче буржуазия вәкилләре түгел, ә мөселман руханилары мохитеннән үсеп чыккан татар зыялылары. Татар җәмгыятенең иҗтимагый-сәяси нигезләренә радикаль мәгърифәт һәм мәдәният реформалары өчен көрәш татар мәгърифәтчеләренең төп шигаре була. 19 йөзнең 2 нче яртысында, патриархаль нигезләр таркалган һәм татар буржуазиясе формалашкан чорда, Т.м. идеологиясе иҗтимагый-сәяси төсмер ала һәм *җәдитчелекнең* бер өлешенә әверелә.

*Әд.:* Валидов Дж. Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.). М.–П., 1923; Аршаруни А., Габидуллин Х. Очерки панисламизма и пантюркизма в России. М., 1931; Фасеев К.Ф. Из истории татарской передовой общественной мысли. К., 1955; Михайлова С.М. Формирование и развитие просветительства среди татар Поволжья (1800–1861). К., 1972; Юзеев А.Н. Татарская философская мысль конца XVIII–XIX веков (эволюция, основные направления и представители). К., 1998. Кн. 1; Адыгамов Р.К. Габдрахим Утыз-Имяни. К., 2005; Идиятуллина Г. Абу-н-Наср Курсави. К., 2005.

**ТАТА́Р МӘДӘНИЯТЕ́ ЙОРТЫ́** (ТМЙ), иҗтимагый башлангычларга, ш.и. фәнни җәмгыятьләргә һәм түгәрәкләргә нигезләнгән, респ-кадагы мәдәни эшне координацияләүче дәүләт оешмасы. ТАССР ХКС карары б-н 1927 елның 4 июнендә ачыла. Аны оештырганда Бакудагы Төрки мәдәният сарае һәм Минскидагы Белорус мәдәнияте ин-ты тәҗрибәсе исәпкә алына. Максатлары: киң җәмәгатьчелекне актив рәвештә җәлеп итеп, фән һәм мәдәният үсешенә булышу; мәдәният һәм фән өлкәсендә татар кадрлары булдыруга ярдәм итү; бергәләп эшләү өчен фәнни җәмгыятьләрне һәм түгәрәкләрне берләштерү; фәнни-пропаганда эшчәнлеге алып бару. *Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте, Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте, «Яңалиф»* җәмгыяте, *Татар пролетар язучылары ассоциациясе, Татарстан Республикасы китап палатасы,* Татарстан пед. җәмгыяте, *Татар совет язучылары оешмасы*, Яшь язучылар түгәрәге, Татар. акад. китапханәсе һәм күп кенә башка оешмалар һәм учреждениеләр эшчәнлегенә җитәкчелек итә; аларның эшчәнлек планнарын раслый; аларның мәнфәгатен дәүләт идарә органнарына җиткерә. ТМЙ җитәкчелеге: директор (З.М.Мөхсинов), 2 нче гыйльми секретарь (Н.Мөхетдинов, П.М.Дульский), президиум (составына карамагындагы барлык җәмгыятьләрдән һәм оешмалардан вәкилләр керә). ТМЙ тирәсенә фәнни оешмалар һәм башка җәмгыятьләрне берләштерү алар эшчәнлегендә җитди мәдәни-әдәби үзгәрешләргә китерми — оешмаларның составы, уставы һәм эшчәнлек юнәлеше саклана. Ләкин алар үз эшләрен ТМЙ эшчәнлеге программасына — «җитештерү көчләренә, халык хуҗалыгына, иҗтимагый хәрәкәт, тел, әдәбият, тарих, этнография һәм революцион хәрәкәт җәһәтендә ТАССРны план нигезендә өйрәнү»гә нигезләнеп планлаштырырга тиеш булалар. ТМЙ фәнни конференцияләр, иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни чаралар үткәрә, күргәзмәләр, лекцияләр һ.б.ны оештыра. ТМЙ хезмәткәрләренең иң киң таралган эш формасы – фәнни-популяр лекцияләр үткәрү; лекцияләр ТМЙ бинасында гына түгел, заводларда, клубларда, мәдәният йортларында һ.б.да укыла. Лекция уку өчен Мәскәүдән, Ленинградтан белгечләр (шәркыятьче галимнәр И.Н.Бороздин, А.Е.Башкиров, А.А.Фёдоров-Давыдов, сәнгать белгече Б.П.Денике һ.б.) чакырыла. 1930 елга кадәр ТМЙ катнашында 11 күргәзмә уздырыла. Иң зур күргәзмәләр Казан ун-тының 125 еллык юбилеена (1929) һәм ТАССР төзелүнең 10 еллыгына (1930) багышлана. ТМЙ китаплар бастыру б-н актив шөгыльләнә; басмалар турында карарлар аның президиум утырышларында кабул ителә (1928–30 еллар эчендә продукциянең гомуми күләме якынча 140 басма табак тәшкил итә). ТМЙ катнашында ш.у. *«Безнең юл», «Мәгариф», «Татарстан», «Вестник научного общества татароведения»*, «Вестник педагогического общества», «Труды Дома татарской культуры» (1–4 т., 1930) ж-ллары нәшер ителә. ТМЙның иң актив хезмәткәрләре архит-ра белгече В.В.Егерев, этнограф Н.И.Воробьёв, тарихчы Н.Н.Фирсов.

ТМЙ функцияләре күп кенә мәсьәләләрдә *Гыйльми үзәк* эшчәнлегенең эчтәлеге б-н кисешә, бу – кабатлануга китерә һәм соңгысының роле кими. ТМЙ ачылган көненнән киләчәктә Татар мәдәнияте ин-тына, соңрак Татарстан Фәннәр академиясенә үзгәртеләчәк учреждение буларак карала. 1930 ның мартында ТМЙ хезмәткәрләренең актив әзерлек эшләре нәтиҗәсендә *Татарстан икътисад фәнни-тикшеренү институты* ачыла, фәнни-тикшеренү эшләре буенча ТМЙ функцияләренең бер өлеше шунда күчә. 1930 ның көзендә ТАССР Мәгариф халык комис-ты карары нигезендә ТМЙның эшчәнлеге туктатыла.

*Әд.:* Мухсинов З. Дом татарской культуры // Очерки по изучению местного края. К., 1930; Фаттахова Г.А., Валеев Р.К. Академический центр Татарии: 1920-е годы. К., 2002.

**ТАТА́Р МӘМӘТХУҖАСЫ́** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 30 *км* көньяк көнбатыштарак, Сөлчә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 98 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб, китапханә. Мәчет. 1614 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Мәмәтхуҗа исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, җил тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1008,66 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ташкабак волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 69 ир-ат; 1859 да — 389, 1897 дә — 681, 1908 дә — 881, 1920 дә — 888, 1926 да — 544, 1938 дә — 508, 1949 да — 370, 1958 дә — 281, 1970 тә — 223, 1979 да — 217, 1989 да — 160, 2002 дә — 110 кеше. Т.М. янында 16 йөз эпиграфик истәлекләре — кабер ташлары сакланган.

**ТАТА́Р МӘХКӘМӘСЕ́ БАШЛЫГЫ́**, *Татар мәхкәмәсе йорты* җитәкчесе. Җирле халыклар арасында мәхкәмә эшләрен башкару өчен рус воеводасы яки дьяклары тарафыннан рус дворяннарыннан билгеләп куелган башлык.

**ТАТА́Р МӘХКӘМӘСЕ́ ЙОРТЫ́**, Урта Иделдә 16 йөзнең 2 нче яртысыннан җирле үзидарә оешмасы. Барлык өяз үзәкләрендә оештырылып, руслардан тыш җирле халыкка бәйле эшләрне карый. Мәхкәмә б-н *татар мәхкәмәсе башлыгы* җитәкчелек итә. 18 йөз башында Пётр I нең мәхкәмә реформалары барышында бетерелә.

*Д.Г.Мостафина.*

**ТАТА́Р МИЛЛИ́ БӘЙСЕЗЛЕ́К ПА́РТИЯСЕ «ИТТИФА́КЪ»**, Россиядәге иҗтимагый-сәяси оешма. *«Иттифакъ әл-мөслимин»* («Мөселманнар берлеге») Россия мөселманнарының революциягә кадәрге либерал-демократик юнәлешле сәяси партия хөрмәтенә шундый исем ала. 1990 елда *Бөтентатар иҗтимагый үзәге* (БТИҮ) төркеме активистлары башлангычы б-н оештырыла. Анда Татарстанның тулы бәйсезлеген яклаучы радикаль фракция барлыкка килә. 1990 ның 27 апрелендә Казанда оештыру конференциясе уза. «Иттифакъ» («И.») партиясенең беренче рәисе Р.Ф.Мөхәммәтдинов, соңыннан Ф.Ә.*Бәйрәмова* була. 1992 дә Т.м.б.п.«И.» респ-ка оешмасы буларак теркәлә. Съезд югары идарә органы булып тора, анда партия рәисе, идарә һәм үзәк контроль-ревизия комиссиясе сайлана. 4 съезды була: 1 нчесе — 1991 нең 13–14 апрелендә (Казан); 2 нчесе — 1993 нең 27–28 февралендә (Чаллы ш.); 3 нчесе — 1995 елның 23 сентябрендә (Түбән Кама ш.); 4 нчесе — 1997 нең 20 декабрендә (Казан). Идарә итүне партиянең башкарма органы формалаштыра: 1991–97 дә Үзәк башкарма советы, 1997 дән — Секретариат. 1992 башында 27 җирле бүлек исәпләнә, аларның Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Бөгелмә шәһәрләрендәге бүлекләре генә активлык күрсәтә. 1990 еллар башында Т.м.б.п.«И.» бүлекләре Татарстаннан читтәге күп кенә шәһәрләрдә (Мәскәү, С.-Петербург, Екатеринбург, Ижевск, Пенза, Саратов, Ульянов) оештырыла. Партиянең җирле бүлекләренең югары идарә органы гомуми җыелыш була, анда рәис һәм координация советы сайлана. Т.м.б.п.«И.» әгъзалары саны: 1992 нең гыйнварында — 525, 1995 нең октябрендә — 2500 ләп кеше.

1 нче съездда партиянең программасы кабул ителә (авторлары — Р.Ф.Мөхәммәтдинов һәм Р.М.Әмирханов). Анда партиянең коммунизмга каршылыгы турында әйтелә, милли мәсьәләне хәл итүнең хәзерге модельләре тәнкыйтьләнә, партия идеологлары фикеренчә, алар колониаль характерда була. Т.м.б.п.«И.»ның стратегик максаты — татар халкының милли бәйсезлегенә ирешү. Идеологик яктан ул халыкара хокук нормаларына (Милләтләрнең үзбилгеләнү хокуклары турында кагыйдәләр) гына түгел, 1552 дә Казан ханлыгын Россиягә мәҗбүри кушып бозылган тарихи гаделлекне торгызу мөһимлеге турындагы тезиска да нигезләнә. Бәйсезлеккә ирешү өчен өч төп мәсьәләне хәл итү күзаллана: 1) татар халкын, барыннан да бигрәк, аның мәдәни гореф-гадәтләрен торгызу; 2) татарларның дәүләти мөстәкыйльлеген кайтару; 3) халыкара хокук субъекты буларак, татар халкының аерылгысыз хокукларын тормышка ашыру. Әлеге мәсьәләләрне хәл итү «милләтчелек, төркичелек, исламчылык» принцибы кысаларында карала. Партия идеологлары дәүләттә капитализм моделен тормышка ашыруны яклап чыгалар, ул вакытта дәүләт зур пр-тиеләрне контрольдә тотарга тиеш, ә шәхси капитал өлкәсе вак һәм урта эшмәкәрлек белән генә чикләнергә тиеш була. Дәүләт контроле милекнең Татарстан гражданы булмаган затлар кулына күчүеннән сакланыр өчен кирәк. Партия крәстиянннәр — Татарстан гражданнары өчен генә җирне шәхси милеккә кертүне яклап чыга.

1990 еллар башында Т.м.б.п.«И.» татар милли хәрәкәтенең радикаль канатын чагылдыручы була. 1991 нең августына кадәр партия ш.у. коммунистик режим б-н актив көрәш алып бара. Әлеге максат б-н 1990 ның җәендә Т.м.б.п.«И.» Татарстан демократик көчләренең Координацион советы әгъзасы була. Ләкин анда респ-ка суверенлыгына каршы сәяси оешмалар өстен булганлыктан, 1991 ел башында Т.м.б.п.«И.» аның составыннан чыга. Төрки бердәмлек идеяләрен яклап, партия җитәкчелеге Төрки халыклар ассамблеясен (1991), Төрки халыклар хокукларын яклау ком-тын (1993) оештыруда актив катнаша. ТР ЮС депутаты, партия лидеры Ф.Ә.Бәйрәмова респ-каның законнар чыгару югары органында (1990–95) Т.м.б.п.«И.» мәнфәгатьләрен чагылдыра. Ул татар милли хәрәкәтенең радикаль канаты активистларының бердәм хәрәкәтен оештыра, аларның вәкилләре (Т.м.б.п.«И.», БТИҮ, «Суверенитет» ком-ты, «Азатлык» татар яшьләре союзы) респ-ка парламенты каршында хакимияткә һәм сәяси оппонентларга психол. басым ясау максатыннан массакүләм митинглар оештыралар.

СССР таркалганнан соң, Т.м.б.п.«И.» вәкилләре: Татарстан җитәкчелеге респ-каны Россиядән аеру юлын тотар, дип уйлый, әмма бу хәл булмый кала. Әлеге шартларда радикаллар параллель рәвештә респ-ка б-н җитәкчелек итүне үз өстенә алырга тиеш булган хакимият структуралары оештырырга омтылалар. 1992 нең февралендә Т.м.б.п.«И.» Бөтентатар корылтаен (съездын) чакыру инициаторларының берсе була, корылтайның күп кенә делегатларыннан татар халкының экстерр. сайланган органы *Милли Мәҗлес* (ММ) формалаша. Аның җитәкчелегендәге төп позицияләр партия вәкилләре һәм аларның тарафдарлары кулында була, тиздән алар ТР ЮСннан хакимиятне үз кулларына алырга тырышалар. Әлеге вакыйгалар б-н бер үк вакытта 1991 ел ахырыннан Т.м.б.п.«И.» һәм радикаль оешмалар яклавында законсыз рәвештә хәрбиләшкән частьлар (Милли гвардия) оештырырга омтылалар, әмма бу омтылыш респ-ка хакимияте тарафыннан туктатыла. Соңрак, 1994–97 дә, Ф.Ә.Бәйрәмова турыдан-туры ММ б-н җитәкчелек итә, әмма ул вакытка инде халык арасында йогынтысы булмый.

Т.м.б.п.«И.»ның Татарстанның рәсми җитәкчелеге б-н мөнәсәбәте, нигездә, капма-каршы була, бигрәк тә респ-ка суверенлыгын тормышка ашыру формалары һәм алымнары буенча, ләкин 1992–94 еллар дәвамында Т.м.б.п.«И.» ачыктан-ачык каршы торуга күчми. Бу шуның б-н аңлатыла, Татарстан хакимияте респ-ка статусы мәсьәләсе турында федераль җитәкчелек б-н сөйләшүләр алып бара. 1994 нең 15 февралендә РФ һәм ТР арасындагы Шартнамәгә кул куелганнан соң партиянең позициясе үзгәрә. Аның тарафдарлары респ-каның Шартнамә нигезендә алган сәяси статусыннан ризасызлык белдерәләр. Әлеге моменттан Т.м.б.п.«И.»ның килешмәүчән оппозиция лагерена күчүе башлана.

1994 тә Татарстанда парламент реформаларын әзерләү процессында татар радикаллары демократик оппозиция вәкилләре һәм коммунистлар б-н «Түгәрәк өстәл» коалициясенә берләшәләр, шул кысаларда ТР сайлау системасын реформалаштыру буенча тәкъдимнәр эшләнә. 1995 тә Т.м.б.п.«И.» ТР Дәүләт Советы сайлауларында актив катнаша, 27 кандидат тәкъдим итә, шулардан фәкать берсе генә (Ф.Г.Шәймәрдәнов) җитәрлек күләмдә тавыш җыя.

1990 еллар уртасында партия кризис кичерә башлый: әкренләп җәмәгатьчелекнең теләктәшлеге сүрелә, финанс чыганаклары кими һ.б. Кайчандыр хәрәкәтнең башында торган күп кенә эшлеклеләр (Р.Ф.Мөхәммәтдинов, Р.М.Әмирханов, Т.Р.Бариев һ.б.) партиядән чыгалар. Татар милли хәрәкәте сүлпәнәю шартларында партия җитәкчелеге кризистан чыгу юлын ислам кыйммәтләренә таянуда күрә. 4 нче съездда Т.м.б.п.«И.» ислам партиясе дип тәкъдим ителә. Әле алдарак, 1996 ның июнендә, партиянең кайбер әгъзалары «Татарстан мөселманнары» хәрәкәтен оештыруда катнашалар. Аның җитәкчесе булып (1992–98) ТР Мөселманнар Диния нәзарәте мөфтие Г.С.Галиуллин сайлана, ул башта Т.м.б.п.«И.» әгъзасы була.

Исламчылык б-н параллель рәвештә партия сулга күчү процессын уза. Коммунизмга каршы позицияләрдән баш тарта, ТР Коммунистлар Партиясе (ТР КП) б-н берләшә башлый. ТР КП б-н хезмәттәшлеге 1994 тә «Түгәрәк өстәл» оппозицион коалиция кысаларында күренә башлый, соңгы елларда ул ныгый бара. Оппозиция өчен уңышлы булмаган ТР Дәүләт Советына сайлаулардан соң (1995), татар радикаллары коммунистлар һәм демократик оппозициянең кайбер вәкилләре б-н берлектә ТРның Халык Советларын — респ-ка парламенты депутатлыгына дәгъва кылган кандидатларның иҗтимагый оешмасын төзиләр, сайлау нәтиҗәләрен танымыйлар. 1996 ның июлендә, РФ президенты сайлаулары тәгәлләнгәннән соң, Т.м.б.п.«И.» ТР КП, «Азатлык» татар яшьләре берлеге һәм Россия гомумхалык берлегенең Казан бүлеге б-н берлектә ТР Халык-патриотик союзын оештыруны яклап чыга. Коммунистлар б-н тыгыз багланышлары өчен Т.м.б.п.«И.» татар милли хәрәкәтенең урта канат вәкилләре тарафыннан гаепләнә, бу да партиянең роле кимүгә китерә.

1990 еллар ахырында Т.м.б.п.«И.»ның эшчәнлеге сүрелә башлый. ТР Дәүләт Советы сайлауларында (1999) аның вәкилләре катнашмый. 2000 еллар башында, асылда, партия

таркала, фәкать Чаллы шәһәрендә генә аның активистлары төркеме эшләп килә.

Басмалары: татар телендә «Иттифакъ» г-тасы, рус телендә «Республика» г-тасы (1990–91, Казан; ике газетаның да мөхәррире — Р.А.Садыйков, иң зур тиражы 2000 данә), татар һәм рус телләрендә *«Алтын Урда»* г-тасы (1993–98, Чаллы ш.; 1994–98 дә баш мөхәррире Р.Б.Хәплехәмитов, иң зур тиражы 5000 данә).

*Әд.:* Программа Татарской партии национальной независимости «Иттифак» // Панорама. 1991. № 6; Терентьева И.В., Беляков Р.Ю., Сафаров М.Ф. Республика Татарстан: политические партии, движения, лидеры. К., 2001.

*М.Ф.Сәфәров.*

**ТАТА́Р МОРЗАЛАРЫ́ МӘҖЛЕСЕ́**, иҗтимагый оешма. Татар бәкләре *Еникиевләр* нәселе вәкиле — С.Х.Еникиев башлангычында оештырыла. Аның Россиядәге татар морзалары нәселләре тарихына багышланган «Чабаталы морзалар» мәкаләсе («Вечерняя Уфа», 1992, 21 февр. г-тасы) басылып чыкканнан соң, 1992 елның язында Уфа шәһәрендә татар морзаларының 15 нәселе вәкилләренең 1 нче очрашуы була, анда оешманың уставы кабул ителә; 1992 нең 5 декабрендә 1 нче гомуми җыелышта Т.м.м.н оештыру турында карар кабул ителә. Мәҗлеснең максатлары: хәзерге социаль-икътисади һәм иҗтимагый-сәяси шартларда татар морзалары нәселләрен яңадан торгызу, татар морзалары сословиесен бергә туплап ныгыту, үсеп килүче буынны татар морзалары традицияләре рухында тәрбияләү. Оешманың төп концепциясе: җимерелгән интеллектуаль һәм рухи кыйммәтләрне яңарту, татар халкы өчен традицион һәм кайчандыр буыннан-буынга күчеп хәзер өзелгән «мөселманнарга хас сабырлык, әхлак идеалларын» — шәхескә хөрмәт б-н карау, милләткә, татар халкына хезмәт итү кебек сыйфатларны торгызу. Эшчәнлекнең төп юнәлешләре: төбәкне өйрәнү эшләре, морза нәселләре тарихына караган архив документларын эзләү, мәгърифәтчелек, телне, динне торгызу. 18 һәм 19 йөзләрдә иң югары Фәрманнар нигезендә Сенат герольдия департаменты тарафыннан билгеләнгән, татар морзалары нәселе фамилиясен йөртүче һәм турыдан-туры морзалар һәм бәкләр нәселеннән булган (ирләр ягыннан) гражданнар Т.м.м. әгъзасы була алалар. Мәҗлеснең идарә итү органнары — гомуми җыен, аксакаллар шурасы (нәсел башлыгы, аерым морза нәселләрен җитәкләүче) — җитәкче һәм аның урынбасарлары. 600 ләп кеше мәҗлес әгъзалары булып исәпләнә, алар арасында морза нәселләреннән *Акчуриннар*, Әюповлар, Бигловлар, Бибарсовлар, Дашкиннар, *Дәүләткилдиевләр*, Дивиевләр, Еникиевләр (морзалар), *Еникиевләр* (бәкләр), Кашаевлар, *Кугушевлар, Кудашевлар, Максутовлар,* Мамлиевләр, Сакаевлар, *Тенишевлар, Терегуловлар, Чанышевлар, Яушевлар* бар. 1992–2006 да мәҗлес әгъзаларының 18 съезды үткәрелә. Оешма Россия дворяннар җыенының ассоциацияләнгән әгъзасы була. Татарстанда Т.м.м вәкилләре: А.Ш.Терегулов һәм Ф.Я.Уразаев. Басма органы — «Морзалар хәбәрчесе» г-тасы, 1994 нең мартыннан татар һәм рус телләрендә Уфа шәһәрендә чыга.

Рәисләре: С.Х.Еникиев (1992 дән), Р.У.Акчурин (1997 дән), М.Ш.Мамлиев (2004 тән), И.М.Доукаев.

*Әд.:* Дворянские роды Российской империи. М., 1996. Т. 3; Еникеев С. Очерк истории татарского дворянства. Уфа, 1999; Габдуллин И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*А.Г.Терегулов.*

**ТАТА́Р МӨШЕГЕСЕ́** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 38 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мөшеге елгасы буенда. 2010 елда 245 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1621 елга кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1773–75 елгы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында Т.М.ндә мәчет (1837 дән мәгълүм), мәктәп, 3 су тегермәне, ашлык саклау-сату һәм 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2483 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 213, 1859 да — 689, 1870 тә — 653, 1884 тә — 867, 1897 дә — 910, 1906 да — 1024, 1913 тә — 799, 1920 дә — 810, 1926 да — 841, 1938 дә — 640, 1949 да — 486, 1958 дә — 390, 1970 тә — 438, 1979 да — 367, 1989 да — 294, 2002 дә — 285 кеше.

*Әд.:* Мензелинский край: История и современность. Мензелинск. 2006.

**ТАТА́Р МУЛЛА́ ИЛЕ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 18 *км* көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 115 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. Мәчет. 1717 гә кадәр нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. Реформалар чорында Т.М.И. 1878–1879 еллардагы *Казан постаучылары чуалышлары* үзәкләреннән берсе була. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 768 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Мораса волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 161 ир-ат (Иске Мулла Иле авылы халкын да кертеп), 1859 да — 485, 1897 дә — 688, 1908 дә — 732, 1920 дә — 854, 1926 да — 713, 1938 дә — 520, 1949 да — 499, 1958 дә — 363, 1970 тә — 447, 1979 да — 350, 1989 да — 202, 202 дә — 148 кеше.

**ТАТА́Р НАРАТЛЫСЫ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 43 *км* көньяктарак, Гөбенә елгасы буенда. 2010 елда 81 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Клуб. Мәчет. 1567 дән рус чыганакларында Наратлеева исеме б-н мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 496 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 36 ир-ат; 1859 да — 202, 1897 дә — 378, 1908 дә — 449, 1920 дә — 385, 1926 да — 319, 1938 дә — 378, 1949 да — 333, 1958 дә — 127, 1970 тә — 248, 1979 да — 212, 1989 да — 116, 2002 дә — 102 кеше. Т.Р.нда тарихчы Г.Н.*Әхмәров* туган.

**ТАТА́Р О́ПЕРА СТУ́ДИЯСЕ**, *дәүләт карамагында.* 1934–38 елларда СССР халыкларының милли кадрларын әзерләү буенча дәүләт сәясәтенә ярашлы рәвештә Мәскәү консерваториясе каршында эшли. Ачылырга тиешле Татар опера театры өчен белгечләр, ш.и. сәнгать җитәкчелеге һәм башкаручылар коллективы әзерләү максатыннан оештырыла. Студиягә укырга респ-каның иҗат эшчәнлеген яңа гына башлап җибәргән һәм инде күпмедер тәҗрибәсе булган иң яхшы мәдәният эшлеклеләре, ш.и. композиторлар С.Сәйдәшев, Л.Хәмиди, М.Латыйпов, М.Мозаффаров, З.Хәбибуллин, Г.Әбделмәнов; дирижёрлар И.Әүхәдиев, Җ.Садриҗиһанов, Х.Фазлуллин; вокалистлар С.Айдаров, У.Әлмиев, М.Булатова, Г.Кайбицкая, М.Рахманкулова, С.Садыйкова, Ф.Маннапов, Л.Верниковский, Х.Зәбирова, Н.Даутов, Ф.Насретдинов; балетм. Г.Таһиров; әдәбиятчылар Ф.Бурнаш, К.Тинчурин, Г.Кутуй, Ә.Фәйзи, Ә.Ерикәй һ.б. җибәрелә. Студиянең директоры итеп реж. С.Вәлиев-Сульва (соңрак — Х.Тәхфәтуллин) билгеләнә, уку-укыту бүлеге мөдире — комп. Җ.Фәйзи, әдәби бүлек мөдире М.Җәлил була. Әлеге уку-иҗат коллективы алдындагы максатлар һәм бурычларның катлаулыгы һәм күптөрлелеге төрле пед. чишелешләр эзләп табуны таләп итә. Индивидуаль уку-укыту планнары башлангыч музыка белеме бирүдән алып, югары музыка уку йортында өйрәнелә торган акад. фәннәрнең тулы бер комплексын үзләштерүгә кадәрге максатларны колачлый. Студиядә укыту эшен Мәскәү консерваториясенең күренекле педагоглары: композиция классы буенча — Г.И.Литинский, Б.С.Шехтер, А.В.Александров, симф. дирижёрлык классы буенча Н.П.Резников, С.С.Бергольц, вокал классы буенча — М.В.Владимирова, Д.Л.Аспелунд, В.И.Садовников, С.И.Друзякина һ.б. алып бара. Режиссёрлык һәм сәхнә эшенә әзерләү б-н Ф.Н.Каверин, Б.А.Мордвинов, С.М.Михоэлс һ.б. шөгыльләнә. Булачак опера һәм балет әсәрләре авторларын әзерләү барышында Литинский методикасы аеруча нәтиҗәле була. Ул, илнең милли муз. культурасы үзенчәлекләрен үзләштереп, күп кенә

респ-калардагы композиторларны тәрбияләүнең иң отышлы юлларын таба. Татар студиясендә вокал бүлеге күпчелекне тәшкил итә. Андагы укытучылар, рус җыр-вокал традицияләре варислары буларак, булачак җырчыларда акад. башкару стиле тәрбиялиләр. Тулаем алганда, студиядәге барлык вокалистлар да тирән проф. әзерлекле була. Режиссёр, хормейстер, балетмейстер, дирижёрларга белем бирү аерым бер үзенчәлекле караш таләп итә. Алар б-н эшләгәндә, стажёрлык ысулы кулланыла (күбесе инде иҗади эшчәнлек тәҗрибәсенә ия була), бу киң иҗади аралашу, остазлар б-н уртак гамәли эш тәҗрибәсе булдыру мөмкинлеге тудыра. Уртак иҗат эшчәнлеге буларак, куелачак премьера спектакльләре әзерләгәндә, студиянең барлык бүлекчәләре дә үзара берләшә. Мәскәү һәм Казанда даими рәвештә концертлар кую практикасы студия эшчәнлегенең мөһим юнәлеше булып тора. Укыган вакытта яшь татар композиторлары сәнгатьчә сурәтләү чаралары һәм стилистик эзләнүләрдә билгеле бер чикләүләргә юлыгалар. Аларның укулары дөньяви муз. процесстан аерымланган хәлдә бара, ул катгый рәвештә 19 йөз Европа һәм рус муз. театрының акад. формаларына юнәлдерелгән була. Узган дәвердәге татар музыкасының үсеш нәтиҗәләрен бәяләп бетермәү тенденциясе дә сизелерлек күзәтелә. Шул сәбәпле билгеле бер вакыт дәвамында милли җирлектә туган муз. драма жанры татар музыкасының төп үсеш юлларыннан читтә була. Оештыру эшендәге һәм иҗади кыенлыкларга карамастан, студия белгечләрнең проф. әзерлеге, милли муз. театрның төп репертуарын булдыру мәсьәләләрен хәл итүгә ирешә. Студияне тәмамлаучылар берничә дистә еллар дәвамында Татар опера һәм балет театры труппасының иҗади актив нигезен тәшкил итәләр, бу аның сәхнәсендә рус, Көнбатыш Европа классик һәм милли репертуарының төп әсәрләре буенча спектакльләр кую мөмкинлеге бирә. Студия эшенә җәлеп ителгән күпчелек иҗат эшлекләләре — И.Әүхәдиев, Җ.Садриҗиһанов, Х.Фазлуллин һ.б. композитор һәм башкаручы булып танылулары өстенә музыка белеме бирү өлкәсендә Татарстанның әйдәп баручы белгечләре дә булып җитешәләр. Студия, уку-иҗат оешмасы буларак, респ-када төрле дәрәҗәдәге проф. музыка белеме бирү системасының үсеш юлында мөһим этапны билгели. Аның эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып, Казанда консерватория ачу ихтыяҗы килеп туа, ул 1945 тә гамәлгә ашырыла.

*Әд.:* Нигмедзянов М.Н. Музыкальный Татарстан. К., 1970; Исанбет Ю.Н. Муса Джалиль и татарская музыка. К., 1977; Салитова Ф.Ш. Татарская оперная студия при Московской консерватории как начальный этап формирования системы высшего музыкального образования Татарстана // Музыка и педагогика: проблемы профессиональной подготовки педагога-музыканта. К., 2007. Вып. 4; Салихова Л.И. Татарская оперная студия при Московской государственной консерватории (1934–1938 гг.): проблемы организации и функционирования // Искусство и образование. 2008. № 5.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ТАТА́Р О́ПЕРА ҺӘМ БАЛЕ́Т ТЕА́ТРЫ** (М.Җәлил исем. Татар дәүләт опера һәм балет акад. театры). 1938 елдан Татар дәүләт опера театры, 1941 дән опера һәм балет театры, 1956 дан М.Җәлил исемен йөртә, 1988 дән акад. театры. Театр ачылу турында карар 1933 нең 4 ноябрендә ТАССР ХКС тарафыннан кабул ителә; 1939 ның 17 июнендә Н.Җиһанов әсәре буенча «Качкын» операсы премьерасы б-н ачыла; беренче балет спектакле («Файдасыз саклык» — «Тщетная предосторожность», П.Гертель) 1939 ның 9 сентябрендә күрсәтелә. 16 ел дәвамында спектакльләр Казан Зур драма театры һәм Татар акад. театры сәхнәләрендә бара, 1956 дан үз бинасында куела башлый. Аның сәхнәсендә куелган беренче спектакль — Н.Җиһановның «*Алтынчәч*» операсы. Театр *Казанда опера сезоннары* (1874 тән) традицияләрен дәвам итә. Труппаның беренче составында *Татар опера студиясен* тәмамлаган З.Байрашева, Г.Кайбицкая, А.Измайлова, С.Садыйкова, М.Булатова, Х.Зәбирова, М.Рахманкулова, Ф.Насретдинов, Н.Даутов, У.Әлмиев, Л.Маев, Л.С.Верниковский, М.Булат-Родионов һ.б. була. Алар — театрда куелган спектакльләрдә төп партияләрне беренче булып башкаручылар. Шул ук вакытта балет труппасы да формалаша башлый (А.Ф.Гацулина, Г.Ш.Әхтәмов, В.П.Романюк, Л.А.Жуков һ.б.). Баштагы чорда театрның сәнгать җитәкчелеге дирижёрлар И.Әүхәдиев, С.С.Бергольц, Җ.Садриҗиһанов, Х.Фазлуллин, реж. Ф.Н.Каверин, балетмейстерлар Г.Таһиров, Ф.Гаскәров, рәссам П.Т.Сперанский, хормейстер П.Федотов тарафыннан тормышка ашырыла. Спектакльләрне ш.у. Татар акад. театры режиссёрлары Ш.Сарымсаков, С.Вәлиев-Сульва да куя. Театр Татарстанның милли опера һәм балет сәнгате үсешенә үз эшчәнлегенең беренче унъеллыгында аеруча зур өлеш кертә («Ирек», «Алтынчәч» (Н.Җиһанов; 1940, 1941), «Галиябану» (М.Мозаффаров; 1940) опералары, «*Шүрәле*» (Ф.Яруллин; 1945) балеты, «*Башмагым*» (Җ.Фәйзи; 1942) муз. комедиясе, «Түләк» операсы, «Зөһрә» балеты (Н.Җиһанов; 1945, 1946). Бер үк вакытта төп классик Европа һәм рус опера һәм балет репертуарын да («Риголетто», «Травиата», Дж. Верди; «Фауст», Ш.Гуно; «Чио-Чио-сан», Дж. Пуччини; «Евгений Онегин», «Аккош күле» («Лебединое озеро»), П.Чайковский; «Жизель», А.Адан; «Коппелия», Л.Делиб һ.б.) үзләштерү бара.

1950–60 елларда әйдәп баручы опера солистлары — З.Хисмәтуллина, В.Шәрипова, Р.Билалова, Г.Сәйфуллина, Б.А.Аполлонов, А.Аббасов, В.Н.Жарков, И.Ишбүләков, В.Т.Степанов; балет артистлары — Н.Юлтыева, Р.Садыйков, Г.С.Калашникова, Ә.Нарыйков, Р.Новицкая, Р.Ибәтуллин һ.б. Бу чорда Н.Җиһановның «*Җәлил*» операсын кую (1957) аеруча зур әһәмияткә ия була, башка татар композиторларының әсәрләре дә куела: «*Самат*», «Дим буенда» (Х.Вәлиуллин), «Намус» (Н.Җиһанов), «Тапшырылмаган хатлар» (Җ.Фәйзи) опералары; «Раушан» (З.Хәбибуллин; балалар өчен), «Тау әкияте» («Горная быль», А.С.Ключарёв), «Алтын тарак» (Ә.Бакиров), «Кисекбаш» (Р.Гобәйдуллин) балетлары. Көнбатыш Европа һәм рус классик репертуары спектакльләре дә гамәлгә ашырыла: «Трубадур», «Аида» (Дж. Верди), «Пики дамасы» («Пиковая дама»), «Мазепа», «Чародейка» (П.Чайковский), «Борис Годунов» (М.Мусоргский) опералары, сирәк башкарыла торган «Джоконда» (А.Понкьелли), «Леньяно янындагы сугыш» («Битва при Леньяно», Дж.Верди); хәзерге заман композиторларының әсәрләре — «Яшен сукмагы буйлап» («Тропою грома», К.Караев) балеты, «Катерина Измайлова» (Дм.Шостакович) операсы (1965). Театр репертуарында оперетталар һәм муз. комедияләр аерым урын алып тора. Бу чорда театрның сәнгать җитәкчелеген дирижёрлар И.Э.Шерман, К.К.Тихонов, реж. Н.Даутов (бер үк вакытта төп опера партияләрен башкаручы), балетм. Л.Бордзиловская, рәссам Ә.Нагаев тәшкил итә.

1960–70 елларда театрда буыннар алмашы, сәнгать җитәкчелегенең (дирижёрлар Ф.Мансуров, В.М.Васильев, Я.Вощак, Ю.Кочнев, И.Лапиньш, В.Куценко; балетмейстерлар Н.Юлтыева, Д.Арипова, Л.Исакова; реж. И.Г.Мәҗитов һ.б., рәссам А.Б.Кноблок) еш алышынып торуы күзәтелә. Алдагы



М.Җәлил исем. Татар опера һәм балет театры.

елларда да театрга уңышлы эшләүче җырчылар килә: Ю.В.Борисенко, Ю.Галявинский, С.Рәинбәков, Р.Мифтахова, Л.Г.Башкирова, З.Сөнгатуллина, К.Румянцева, Ә.Заһидуллина, А.С.Фадеичева, Р.Дәминов, Э.Г.Трескин; балет артистлары И.Хәкимова, С.Хантимерова, Л.Хуторова, К.Гайнуллин, Н.Сәрвәров, В.Бортяков, В.Яковлев һ.б. Куелган спектакльләре арасында «Дон Жуан» (В.А.Моцарт), балалар өчен «Мәкерле песи» (Л.*Хәйретдинова*) операсы, «*Су анасы*» (Ә.Бакиров), «Ике легенда» (Н.Җиһанов), балалар өчен «Сихерләнгән малай» («Заколдованный мальчик», З.Хәбибуллин) балетлары бар.

1975 тән театр тарихында башкаручыларның индивидуаль үзенчәлекләрен үстерергә омтылган баш режиссёр, мәшһүр театр һәм музыка эшлеклесе Н.Даутов дәвере башлана. Бу чорда З.Сөнгатуллина, Х.Бигичев, С.Рәинбәков, Р.Сәхәбиев, Г.Казанцева, Г.Ластовка, М.Якупов, К.Хәйретдинова, В.Ганиева, Р.Үзбәкова, Н.Путилин, А.С.Фадеичева, К.Румянцева һ.б. бертөркем опера сәхнәсе осталары иҗади үсешкә ирешә. Н.Даутов куйган спектакльләр гадәти булмаулары, күп



М. Җәлил исем. Татар опера һәм балет театры спектакльләреннән күренешләр: 1. «Качкын», Н. Җиһанов. 1939; 2. «Шүрәле», Ф. Яруллин. 1945; 3. «Алтынчәч», Н. Җиһанов. 1957; 4. «Пики дамасы», П. Чайковский. 1960; 5. «Башмагым», Җ. Фәйзи. 1967; 6. «Отелло», Дж. Верди. 1988; 7. «Аида», Дж. Верди. 2000; 8. «Шүрәле» балетыннан күренеш, Ф.Яруллин. 2011; 9. «Алтын Урда» балетыннан күренеш. Р.Ахиярова. 2013.

очракта сәнгатьчә чишелештә яңалык алып килүләре б-н аерылып тора: «Севилья чәчтарашы» («Севильский цирюльник», Дж. Россини), «Травиата» (Дж.Верди), «Кармен» (Ж.Бизе), «Фауст» (Ш.Гуно), «Богема» (Дж.Пуччини). Бу елларда татар композиторларының яңа опералары куела: «Җиһангир» (Р.Гобәйдуллин), «Кара йөзләр» (Б.Мөлеков).

1980 елларда театрның (сәнгать җитәкчелегендә классик әсәрләрне үзенчә аңлатырга омтылган реж. В.Раку; хормейстерлар Н.*Җураева*, И.Рәхимуллин; балетм. Л.Таубе; рәссам В.Немков) аеруча күренекле спектакльләре арасында «Риголетто», «Отелло» (Дж.Верди), «Очучы голланд» («Летучий голландец», Р.Вагнер), «Кар кызы» («Снегурочка», Н.Римский-Корсаков), «Ерактагы кәккүк авазы» (Р.Кәлимуллин) опералары аерым игътибарга лаек. Е.Михайлова, З.Хәйретдинов, балет артистлары Н.Мәһдиева, З.Хәмдиева, Л.Мөхәммәтгалиева, Е.Щеглова, Р.Әбүлханов, И.Жуков һ.б. солист буларак ачылалар.

1980 еллар ахырыннан директор Р.*Мөхәммәтҗанов* театрның сәнгати-адм. төзелешенә үзгәрешләр кертә башлый. Ул, репертуарлы театр үзенчәлекләрен өлешчә саклап калган хәлдә, контракт төзеп эшләү системасын кулайрак күрә, ягъни спектакльләрдә катнашу өчен танылган башкаручылар, режиссёрлар, хореографлар, сценографларны чакыра, традицион сәнгать җитәкчелеген тәшкил иткән вазифалардан баш тартып (баш дирижёр Р.*Салаватовтан* кала), опера (Г.Хәйбуллина, 2010 га кадәр) һәм балет (В.*Яковлев*) буенча аерым сәнгать җитәкчелеге вазифаларын булдыра. 1990 еллардан репертуар сәясәтендә театр җитәкчелеге антология принцибына таяна. Театр коллективының сәнгати мөмкинлекләр диапазоны киң: «зур опера» һәм «зур балет» стилендә эшләнгән акад. пландагы спектакльләрдән алып, автор җитәкчелегендәге яки чорның мәшһүр дирижёрлары, режиссёрлары, сценографлары, хореографлары иҗат иткән тәҗрибә характерындагы спектакльләргә кадәр куела. Төп классик опера һәм балет спектакльләре күрсәтелә, хәзерге заман авторларының, ш.и. Татарстан композиторларының әсәрләре дә сәхнәләштерелә. Театр илебезнең һәм чит илләрнең атаклы театрларында куелган танылган спектакльләрне турыдан-туры гәүдәләндерү б-н бергә дөнья театр һәм музыка сәнгате үсешенең иң актуаль тенденцияләрен чагылдыручы төрледән-төрле сәнгатьчә чишелешләрдән дә актив файдалана. Моңа театрның техник яктан җиһазланышы шактый киңәю дә булышлык итә. 1991 дән барлык спектакльләр дә оригинал телдә башкарыла. Төрле илләрдән (Италия, Нидерландия, Бөекбритания, Һиндстан, Канада, Көньяк Африка Респ-касы һ.б.) килгән сәхнәгә куючы төркемнәр б-н уртак иҗат проектлары гамәлгә ашырыла. Спектакльләре арасында «Фигароның өйләнүе» («Свадьба Фигаро»), «Тылсымлы флейта» («Волшебная флейта»), «Дон Жуан» (өчесе дә — В.А.Моцарт), «Лючия ди Ламмермур» (Г.Доницетти), «Трубадур», «Фальстаф» (Дж.Верди), «Энҗе эзләүчеләр» («Искатели жемчуга», Ж.Бизе), «Борис Годунов» (М.Мусоргский); Татарстан компози-

торларының әсәрләре — «Йосыф кыйссасы» балеты (Л.Любовский; РФнең Дәүләт бүләге, 2006), «Шагыйрь мәхәббәте» операсы (Р.Ахиярова; ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 2008; төп партияне башкарган Ә.*Агади* — «Иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә РФнең «Алтын битлек» милли театраль бүләге лауреаты, 2008) һ.б. бар.

1990 еллардан театрның чит илләргә даими гастрольләре башлана (Бельгия, Бөекбритания, Германия, Австрия, Дания, Швеция, Швейцария, Нидерландия, Португалия, Дания, Франция һ.б. илләрдә ел саен 100 дән артык спектакль күрсәтә); 1982 дән ел саен илебез һәм чит илләрдән күпләгән опера һәм балет йолдызлары катнашында *Шаляпин Ф.И. исемендәге опера фестивале* (1991 дән халыкара), 1987 дән *Нуриев Р. исемендәге классик балет фестивале* (1992 дән халыкара, 1993 тән Р.Нуриев исемендә) уздыра. Театр — Татарстанның дөнья, Россия, татар театр һәм музыка сәнгатен пропагандалаучы гаять әһәмиятле муз. культура үзәкләренең берсе. «Алтын Урда» спектакле өчен театрның иҗат төркеме: Р.С.*Мөхәммәтҗанов*, Г.А.*Ковтун*, К.А.Андреева, М.И.Тимаев ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге б-н бүләкләнәләр (2015). Театр ТР Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләге лауреаты (2016).

Театр бинасы 1936 да арх. Н.П.Скворцов проекты буенча төзелә башлый. 1948 дә арх. И.Г.*Гайнетдинов* бинаның фасад һәм интерьерларына, антик бизәк һәм татар халкының гамәли бизәлеш сәнгате элементларын берләштереп, совет неоклассицизмы стилендә үзгәрешләр кертә. Ян-яктагы ярымтүгәрәк фасадларда А.С.Пушкин (скульп. Н.К.Вентцель) һәм Г.Тукай (скульп. Е.И.Шулик) һәйкәлләре урнаштырыла. Театр интерьерларын бизәү эшендә скульп. В.В.*Ламмерт* һәм рәссам Ч.Г.*Әхмәров* катнаша. 1996 дан театрда төзәтү эшләре алып барыла, 2003 тә реконструкциягә ябыла, ул 2005 тә тәмамлана. Бинаны реконструкцияләү проектының баш архитекторы — А.-Р.Ш.Дустиев.

Бина эчен бизәгәндә бетон, гипс гранит һәм мәрмәр б-н алыштырыла, имән паркет җәелә. Заллар аксыл-алтынсу төстә. Баскыч мәйданчыклары көзгеләр б-н бизәлә. Вакытлар үтү б-н, җуелган детальләр һәм сылап ясалган калку бизәкләр тергезелә. Залның сыйдырышлылыгы 1300 урыннан 950 урынга кала, идәннең авышлыгын үзгәртү хисабына күрү мөмкинлеге яхшыра. Зал үзгәртеп эшләнгән оркестр чокыры, заманча яктырту чаралары һәм акустик техника б-н җиһазландырыла.

*Әд.:* Татарский государственный театр оперы и балета им. М.Джалиля. К., 1957; Гиршман Я.М. Пути развития татарской советской музыки // Музыкальная культура Советской Татарии. М., 1959; Шумская Н. Татарскому оперному театру 20 лет // Советская музыка. 1959. № 10; Татарский академический театр оперы и балета им. М.Джалиля. К., 1994. *Ф.Ш.Салитова.*

**ТАТА́Р ПЕН-ҮЗӘГЕ́**, ТР язучыларының иҗтимагый оешмасы. 1995 елда оеша. 1996 дан Халыкара Пен-клуб әгъзасы (P.E.N., ингл. кыскартылган, poets — шагыйрьләр, essayists — очеркистлар, novelists — романистлар, 1921 дә төзелә). Аның хартиясенә буйсына, лингвистика һәм әдәби тәрҗемә ком-тларының эшчәнлегендә актив катнаша. Ел саен уздырыла торган бөтендөнья язучылар конгрессларында, төрле халыкара һәм региональ әдәбиятчылар форумнарында, хокук яклауга юнәлдерелгән акцияләрдә катнаша. Татар әдәбиятын инглиз телендә бастырып чыгара. 2014 тә 30 әгъзасы бар. Президентлары — Т.Г.Миңнуллин (1995–2010), Р.И.Вәлиев (2010 нан).

**ТАТА́Р ПОЭ́ЗИЯСЕ**. Татар әдәбиятында поэзия — фикер, хисләрне чагылдыруның иң борынгы төре. Элек-электән халыкта шигъри формада лирик һәм йола җырлары туа. Алар авторның индивидуальлеген чагылдырган проф. поэзия үсеше өчен нигез булып торалар. Төрки телле язма әдәбиятларның беренче үрнәкләре булып *орхон-енисей язмалары* (7–8 йөзләр) санала. 11 йөздә *Баласагуниның* «Котадгу белег» поэмасы — гомумтөрки мөселман әдәбияты ядкәре языла. Урта гасыр төрки-татар әдәбиятында аеруча киң таралган әсәрләрдән Кол Галинең «*Кыйссаи Йосыф*» поэмасы (1236) була. Анда заманның әхлакый һәм фәлсәфи мәсьәләләре күтәрелә, гомумкешелек кыйммәтләре раслана. Алтын Урда чоры бер төркем талантлы шагыйрьләр үстерә: Мәхмүд Болгари («Нәһҗел-фәрадис»), Сәйф Сараи («Китабе Гөлестан бит-төрки»), Харәзми («Мәхәббәтнамә»). Казан ханлыгы чорында татар әдәбияты тарихына «Төхфәи мәрдан», «Нуры содур» кебек дидактик поэмалар авторы Мөхәммәдъяр, фәлсәфи-әхлакый эчтәлекле лирик шигырьләре, афористик *хикмәтләре* б-н шагыйрьләр Өмми Камал, Кол Шәриф килеп керәләр. Казан ханлыгы яулангannan соң (1552), 18 йөзнең уртасына кадәр татар әдәбияты торгынлык чоры кичерә. Ул 17 йөзнең 2 нче яртысыннан Мәүлә Колый һәм Габди иҗатларында үсә башлый. Әсәрләрендә алар дини-дидактик сюжетларга, Шәрекъ әдәбиятының эстетика принципларына һәм жанрларына таянып иҗат итәләр. 18 йөз — 19 йөзнең 1нче яртысы шагыйрьләре Ә.Каргалый, Ш.Зәки, Һ.Салихов, шагыйрь һәм галим Г.Утыз Имәни, Аллаһка мөрәҗәгать итеп, дөньяның фанилыгына, кеше язмышының фаҗигалелегенә зарланып, күбесенчә романтик мотивларны үстерәләр. Суфи шагыйрьләр (к. *Суфичылык әдәбияты*) җирдәге тормышны яктылык һәм тереклек чыганагы Аллаһ тарафыннан җибәрелгән язмыш дип кабул итәләр. Алар шигъриятенең асылы — Аллаһны интуитив рәвештә танып белү, аның б-н мистик бәйләнешкә керү. 19 йөздә Т.п. әкренләп дини-дидактик поэтикадан арына, үз чорының проблемаларына, кешенең эчке дөньясын ачуга мөрәҗәгать итә башлый. Мондый борылыш Г.Чокрый, Я.Емельянов, Г.Кандалый исемнәре б-н бәйле. Г.Кандалый поэзиясе дөньяви шатлыкларны сурәтләве, интим кичерешләрнең көчле чагылышы, халык теленә, иҗатына таянуы б-н аерылып тора. Аның «Сәхипҗамал», «Фәрхи», «Мәгъшукнамә» поэмалары мәхәббәт сагышын дөньяви-реалистик буяуларда чагылдыра. Кандалыйның мәхәббәт лирикасы — татар мәгърифәтчелек романтизмының югары нокτасы. 19 йөзнең 2 нче яртысы Т.п. жанрлар төрлелеге б-н үзенчәлекле (*газәл, робагый, фәрд*, хикмәт, *мәдхия, мәрсия* һ.б.). Бу чорның күренекле вәкилләреннән берсе — Акмулла – байлар, муллаларның әхлакый азгынлыгын, һ.б. кимчелекләрне фаш итүче лирик сатира-экспромтлар авторы.

20 йөз башында Т.п., алдынгы әдәбиятлар б-н араны кыскартып, тизләтелгән үсеш кичерә. Бу процесста төп рольне Яңа дәвер татар реалистик поэзиясенә нигез салучы Г.Тукай уйный. Бу елларда Т.п.ндә Дәрдемәнд, М.Гафури, С.Рәмиев, Ш.Бабич һ.б. исемнәре танылa. Татар әдәбияты төрле стилистик эзләнүләр, тормышны чын реалистик тасвирларга омтылу б-н характерланган «алтын дәвер»гә аяк баса.

1917 елгы Окт. рев-циясен татар шагыйрьләре төрлечә кабул итә: берәүләре, аеруча яшь буын вәкилләре (Ф.Бурнаш, Ш.Фидаи, И.Йосфи, К.Нәҗми, Г.Кутуй һ.б.), рев-ция һәм сугышларны җәмгыять тормышын яңарту ысулы буларак кабул итеп, иҗади күтәрелеш кичерәләр; 20 йөз башында әдәбиятка килгән шагыйрьләр (Дәрдемәнд, С.Сүнчәләй, Н.Думави һ.б.) — илдәге хәлне үткәннәрнең мәңгелек кыйммәтләре җимерелү буларак, ә кайберләре фаҗига итеп кабул итәләр. Бу чорда әдәбиятка киләчәктә татар әдәбиятының горурлыгы булып китәчәк талантлы яшьләр килеп кушыла (Һ.Такташ, Х.Туфан, С.Баттал, М.Җәлил, Ш.Маннур һ.б.). Т.п.ндә аеруча ода, гимн, марш, *баллада* жанрлары киң танылa. Чор фәлсәфәсен, кешенең рухи дөньясын ачуда Т.п. яңа үрләр яулый (Һ.Такташ, «Җир уллары трагедиясе», «Алсу», «Мокамай»; Х.Туфан, «Урал эскизлары», «Бибиевләр» һ.б.).

1930 елларда Т.п. авыр чор кичерә. Әдәбиятта коммунистик идеология диктаты, соц. реализм ысулы урнаштыру поэзиянең сәнгати мөмкинлекләренең ярлылануына китерә. Әдәбияттан сатира, фантастика, чынбарлыкка тәнкыйди мөнәсәбәт юкка чыга, халык җырлары, вакыйгалы-эпик поэма жанрлары киң тарала. Популяр пейзаж лирикасы тирән идея-эмоциональ, лирик эчке мәгънә ала (Ә.Фәйзи, Ш.Маннур, М.Җәлил). Сталинизм елларында татар әдәбияты югалтуларга дучар ителә: Х.Туфан, Г.Мөхәммәтшин, Ф.Бурнаш, Ф.Кәрим һ.б. репрессияләнә.

Бөек Ватан сугышы яңа сынаулар алып килә; татар әдәбиятының күп кенә вәкилләре, ш.и. М.Җәлил, Ф.Кәрим, Г.Кутуй, А.Алиш һ.б. һәлак була. Агитацион характердагы сугыш еллары Т.п. героик-романтик юнәлештә дә үсә (Ф.Кәримнең «Гөлсем», «Идел егете», «Үлем уены», «Партизан хатыны» поэмалары, С.Хәким, Н.Арсланов, Г.Хуҗи шигырьләре һ.б.).

Сугыштан соңгы елларда янә сүз ирекен чикләү, тормыш чынбарлыгыннан читкә китү күзәтелә башлый. Поэзиядә юлбашчыларны һәм илдәге «бәхетле» тормышны мактаган, «шомартылган» шигырьләр күбәя. М.Җәлилнең фашист зинданында язылган «Моабит дәфтәрләре»ндәге, Х.Туфанның Сталин лагерьларында, сөргендә язылган шигырьләре Т.п.нә идея-эстетик яктан яңа сулыш

алып килә. Аларның гражданлык пафосы, лирик ихласлыгы, югары сәнгать дәрәҗәсе 20 йөзнең 2 нче яртысы Т.п.нең характерын билгели.

1960 елларда, «Хрущёв җепшеклеге» чорында, эчкерсез лиризм б-н сугарылган шигырьләр б-н поэзиягә яңа, талантлы каләм осталары, укучы б-н иркен телдә сөйләшүче буын килә. Т.п.нең тематика, жанр диапазонының баюы, лирик башлангычның көчәюе Г.Афзал, Ә.Баян, С.Сөләйманова, Ш.Анак, И.Юзеев, Ә.Рәшит, Роберт Әхмәтҗанов, ш.у. яшьрәк буын вәкилләре: Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Гәрәй Рәхим, Р.Мингалим, Р.Гатауллин, К.Сибгатуллин, Б.Сөләйманов, Ф.Яруллин, соңрак — тагын ун елдан — М.Әгъләмов, Зөлфәт, Разил Вәлиев, М.Галиев, З.Мансуров, Х.Әюпов, Р.Миңнуллин, Р.Низамиев, М.Мирза һ.б.ның исемнәре б-н бәйле.

20 йөзнең 2 нче яртысы Т.п.нә шәхеснең кабатланмаслыгын раслау, хиссилекнең гражданлык пафосы б-н үрелеп баруы, жанр төгәллеге, иҗек кыскалыгы һәм фикер ачыклыгы хас. 1920–40 та әдәбиятка килгән сүз осталары икенче яшьлекләрен кичерәләр: Х.Туфан, С.Хәким, С.Кудаш, С.Баттал, Н.Арсланов, Ш.Маннур нечкә лиризм б-н халык тормышының тирән катламын, милли колоритын, замандашларының рухи дөньясын ачалар. Ш.Галиев, Р.Миңнуллин, Р.Корбан һ.б.ның иҗатларында балалар шигърияте үсүен дәвам итә. Җыр жанрының поэтик үзенчәлекләре М.Ногман, Г.Зәйнашева, М.Шиһапов, Ш.Җиһангировалар иҗатында ачыла. Халык иҗаты байлыкларын, Г.Тукай традицияләрен яңа шартларда үстерүгә омтылу яңа көч б-н күтәрелә. Ф.Гыйззәтуллина, Л.Шагыйрьҗан, Э.Шәрифуллина, Б.Рәхимова, К.Булатова, Н.Измайлова, А.Юнысова, Р.Харрасова, Ф.Тарханова, Ф.Солтан һ.б. шигъриятебезне төрле юнәлешләрдә үстерәләр. 20 йөз ахыры — 21 йөз башында шагыйрьләрнең милли мәсьәләләргә, халыкның менталитетын, үзенчәлеген, туган телен саклауга игътибары көчәя төшә (Рәшит Әхмәтҗанов, И.Гыйләҗев, А.Хәлим, Ә.Гадел, Җ.Сөләйманов, Н.Сафина, Г.Моратов, Р.Зәйдулла, Н.Акмал, Л.Янсуар, Р.Мөхәммәтшин).

Бүгенге Т.п.нә эчтәлек байлыгы, жанр һәм стильләрнең төрлелеге, югары сәнгатьлелек хас.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. К., 1984–2001; Татар поэзиясе антологиясе: 2 томда. К., 1992; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек: 2 томда. К., 2009. Т. 1–2. *Т.Н.Галиуллин.*

**ТАТА́Р ПРО́ЗАСЫ**. Фольклордагы һәм урта гасырлар әдәбиятындагы *дастан* һәм *кыйсса* жанрларыннан үсеп чыга. Т.п.ның формалашуы өчен автор б-н геройның аерымлануы шарт. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Котбның «Хөсрәү вә Ширин» һ.б. поэмаларда автор һәм геройның төрле кыйммәтләр дөньясына каравы (герой «абсолют үткәндә»), данлау интонациясен эпик объективлык б-н кушу, тасвирлауның җентеклелеге эпик стиль сыйфатлары булып китә. Урта гасырлар кануны чикләрендә башка эпик жанрлар да яши: намә, рисалә, хикәйәт, китаб. Төрки-татар әдәбиятларында поэзия б-н проза аралаштырылган кысалы кыйсса киң таралa: Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия», Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис», Сәйф Сараиның «Китабе Гөлестан бит-төрки» һ.б. әсәрләр. Шәрекъ мавыктыргыч әдәбиятының бер төре — дастаннар — 1820 еллардан алып 20 йөз башына кадәр кабат активлаша. Хикәйәт, әкият, поэмаларда әкияти-фантастик мотивлар нәсыйхәт б-н үрелеп китә, герой үзенең эпик-героик статусын югалта, сюжет кинaя чарасы булып хезмәт итә башлый.

Яңа, реалистик Т.п.ның, аның төп жанрлары роман, повестьның формалашуы 19 йөзнең 2 нче яртысына — татар мәгърифәтчелек әдәбиятының чәчәк аткан чагына туры килә. М.Акъегетнең «Хисаметдин менла» исемле беренче татар романында иҗтимагый файдалы эшчәнлекнең, халыкны укыту-агартуның, хатын-кыз эмансипациясе мәсьәләләрен хәл итүнең кирәклеге раслана. З.Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында беренче планга социаль мотив — акча мәсьәләсе чыга. Т.п.нда мөһим рольне юлъязмалар уйный. Аларда авторларның мәгърифәтчел карашлары аеруча ачык чагыла, наданлык һәм артта калганлыкны, искергән укыту системасын, хатын-кызның җәмгыятьтәге изелгән хәлен тәнкыйтьләү өстенлек итә, милләтне укыту-агартуга, аны Европа цивилизациясе дәрәҗәсенә күтәрүгә, Европа мәдәнияте казанышларын үзләштерүгә өндәү яңгырый. Бу идеяләр Р.Фәхретдин, Ф.Кәрими, Г.Исхакый, Г.Чыгтай, З.Һади, Ш.Мөхәммәдов кебек мәгърифәтче язучылар иҗатларында чагылыш таба. Бер яктан, Т.п. татар җәмгыятенең көндәлек тормышына якынлаша, икенче яктан, эстетик юнәлешен үзгәртә башлый. Үзенең фантастик-публицистик формасы, уен элементлары, символлары б-н Г.Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повесте шартлы-метафорик проза үрнәге булып, социомәдәни әһәмияткә ия гомумиләштерүләр ясарга мөмкинлек бирә. Анда татар яшәешенең төп проблемасы — милләт язмышы мәсьәләсе күтәрелә. Идея-эстетик борылыш билгеләре күзәтелгән беренче әсәрләр арасында Г.Исхакыйның «Теләнче кыз» романын, «Тормышмы бу?» повестен, Ф.Әмирханның «Гарәфә көн төшемдә», «Картайдым», Ш.Камалның «Уяну» хикәяләрен атап булыр иде. Аларда аермачык рәвештә яңа эстетик юнәлешкә — психологизмга йөз тотыла. Матурлык, идеал, тормышта үз урынын (Ф.Әмирханның «Урталыкта», Г.Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романнары), бәхет (Ш.Камалның «Авыл мөгаллиме» хикәясе, «Акчарлаклар» повесте) эзләүче милли зыялылар вәкилләре; тамак хакына ил гизгән сезонлы эшчеләр (Ш.Камалның «Ата», «Козгыннар оясында» хикәяләре) геройларның катлаулы кичерешләрен тасвирлау вакытында фон хезмәтен үти. Г.Ибраһимов («Карт ялчы», «Көтүчеләр» хикәяләре), М.Гафури («Ярлылар, яки Өйдәш хатын») иҗатында социаль мотивлар, идеаль гармонияле гади кеше образын сурәтләү теләге көчле. Азатлыкка омтылган хатын-кыз язмышы үзәк темаларның берсен били (Г.Исхакыйның «Теләнче кыз» романы, Ф.Әмирханның «Хәят» повесте һ.б.). Мифлаштыру 20 йөз башы романтик Т.п.ның төп сыйфатларыннан берсенә әйләнә (М.Гафуриның «Болгар кызы Айсылу», «Хан кызы Алтынчәч»; Н.Думавиның «Болгар кызы Тойгы туташ»; Ф.Әмирханның «Халык кызлары»; Ш.Әхмәдиевнең «Хан кызы» һ.б.). Этнографик мотивлар, милли менталитетны үзәккә кую Г.Исхакый әсәрләренә хас («Мулла бабай» романы, «Остазбикә» повесте). Романтик прозаның зур формаларына (Г.Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр», «Безнең көннәр» романнары) тормыш-чынбарлык тудырган драматик кичерешләр үтеп керә, алар психоанализ тирәнлеге б-н аерыла. 20 йөз башы татар әдәбиятында модернизм мөстәкыйль юнәлеш булып формалашып җитми, әмма импрессионистик (Ф.Фәйзинең «Көймәдә», Г.Исхакыйның «Бер манзара», Ф.Әмирханның «Яз исереклегендә» хикәяләре) һәм экзистенциаль (Ф.Әмирханның «Бер хәрабәдә», М.Хәнәфинең «Бер гөл бакчасында», «Сөю — җәллад», Н.Гасрыйның «Мазарстанда» хикәяләрендә) юнәлештәге әсәрләр авангард алымнар һәм сәнгать чаралары б-н әдәбиятны баеталар.

1920–50 еллар Т.п.сы сәяси һәм идеологик факторлар басымы астында була, совет чорындагы иҗтимагый-сәяси процесслар б-н тәңгәл үсә. Г.Ибраһимовның «Адәмнәр», К.Нәҗминең «Тукран даласы» повестьларында 1921 елгы ачлыкны тасвирлау әдәбиятта публицистиклык һәм натурализмның көчәюен күрсәтә. Окт. рев-циясен, Гражданнар сугышын сәнгати шәрехләү Ш.Усманов («Ил кызы», «Краском мәхәббәте»), А.Шамов («Рәүфә», «Днепр буенда») иҗатларында героик хикәя жанрын җанландырып җибәрә. Аларда шәхеснең массалар эчендә эреп югалуы лирик планда тулыландырылып, турыдан-туры автор позициясен чагылдыра. Романнар, беренче чиратта, традицияләр җимерелгән, яңа иҗтимагый аң формалашкан чорны эстетик яктан аңлату максатына җавап бирә (Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы). Зур эпик формадагы әсәрләр тарихи схемага (М.Галәүнең «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр», Г.Ибраһимовның «Казакъ кызы» романнары) яки гаилә хроникасына (Г.Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми», М.Гафуриның «Кара йөзләр» повестьлары) якыная. Кешенең яңа дөньядагы урынын яңача тасвирлау ихтыяҗы прозаикларны шәхес язмышын эпохаль вакыйгалар янәшәсенә куярга, еш кына рев-циягә кадәрге авылны кара буяулар б-н тасвирларга мәҗбүр итә. Эпик жанрлар арасында иң алда повесть тора, аның игътибары күбесенчә героик-трагик һәм героик-романтик күренешләргә юнәлтелә. 1920 еллар уртасыннан формалаша башлаган соц. реализм эстетикасы язучыларга карата аерым бер таләпләр (поэтиканың тормышка якынайтылуы, характерларның социаль-сәяси сәбәпләр тәэсирендә үзгәрүе, персонажлар системасында конкрет амплуалар һ.б.) кую б-н генә чикләнми, кулайрак дип табылган темаларны да билгели. Шуңа да 1930 елларда реализм кумәкләштерүгә (Ш.Камалның «Матур туганда» романы, М.Әмирнең «Агыйдел» повесте), Гражданнар сугышына (Г.Бәшировның «Сиваш»,

А.Шамовның «Госпитальдә» повестьлары) багышланган әсәрләрдә раслана. Хәтта яңа кешене романтик буларак тасвирлаганда да мондый күрсәтмә һәм клишеләр үзләрен нык сиздерә (Г.Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте). Бу еллар прозасында өлкән буын язучыларның рев-циягә кадәрге символизм казанышларын торгызу, форма өлкәсендә авангард эзләнүләргә, символлар теленә, импрессионистик буяуларга мөрәҗәгать итү омтылышы сизелә (Ф.Әмирханның «Тәгъзия», «Беренче ашкыну» хикәяләре, Гали Рәхимнең «Идел» повесте). Т.п.сының гомуми фонында Ф.Әмирханның яшәп килүче идеологиягә каршы язылган «Шәфигулла агай» сатирик повесте аерылып тора. Анда революцион идеянең җимергеч көче, кеше аңына басым ясавы ышандырырлык итеп күрсәтелә.

Бөек Ватан сугышы елларында публицистик әсәрләр, ш.и. сугыш вакыйгаларына багышланган очерк һәм хикәяләр мөһим роль уйный башлый, шул ук вакытта авторлар кеше эш-гамәлләренең психол. һәм социаль табигатен өйрәнүгә өстенлек бирәләр (И.Газинең «Алар өчәү иде» повесте, Г.Әпсәләмовның «Ил улы» хикәясе; Ә.Еникинең «Ана һәм кыз», «Бер генә сәгатькә» хикәяләре). Сугыш чоры вакыйгаларын героик-романтик күзлектән сурәтләү Ф.Кәримнең «Разведчик язмалары» һәм «Язгы төндә» повестьларында һ.б.да күзәтелә; аналитик һәм социол.-психол. повестьлар барлыкка килә (Ф.Хөсни «Йөзек кашы»). Кешенең рухи дөньясын романтик тасвирлауга омтылыш *нәсер* жанрының яңаруына китерә (Г.Кутуй, «Сагыну», «Без — сталинградчылар»).

1950 елларда Т.п.нда дәүләт идеологиясе б-н авазлаш героик-романтик юнәлеш өстенлек итә. Кеше масштаблы сәяси вакыйгаларда катнашучы буларак тасвирлана торган (И.Гази, А.Шамовның хикәя һәм повестьлары, Г.Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр», «Алтын Йолдыз», «Газинур» романнары һ.б.) киң колачлы әсәрләр иҗат ителә. Соцреализм роман жанрының тарихи-биографик һәм тарихи-революцион формалары тууга китерә (К.Нәҗминең «Язгы җилләр», И.Газинең «Онытылмас еллар», Ә.Фәйзинең «Тукай» романнары). Аларда рев-ция һәм рев-циядән соңгы еллардагы чынбарлыкның әхлакый-психол. яклары яктыртыла. Сугыштан соңгы еллар романнарында хикәяләүнең эпик колачы лирик башлангыч б-н үрелеп китә, әсәрләрне лирик эпопеяга (Г.Бәшировның «Намус»ы, М.Әмирнең «Саф күңел»е) якынайта. Лирик юнәлеш, психологизмның, экзистенциаль башлангычның тирәнәюе шәхес психологиясен, кешенең дөньяга карашын чагылдыруны максат итеп куйган байтак прозаикларга хас (Ә.Еникинең «Саз чәчәге», «Рәшә», Ф.Хөснинең «Авыл өстендә йолдызлар» повестьлары).

1960–80 елларда ике тенденция: соцреализм принципларына таянган рәсми һәм күпгасырлык татар әдәбиятының эстетик кыйммәтләренә нигезләнгән традицион-гуманистик тенденцияләр өстенлек итә. Сугыш хәрәкәтләрен тасвирлауда героик-романтик юнәлеш (Ш.Рәкыйповның «Кайдан син, Жан?», «Кипарислар җыры» повестьлары), психол. натурализм (Г.Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше», Ш.Маннурның «Муса» романнары, Н.Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында», «Җимерелгән бастион» повестьлары) мөмкинлекләрен файдалану сәбәпле, әсәрләр эмоциональ тәэсирлерәк, аларда сугыш чорының көндәлек ваклыкларын, анда гади катнашучыларны, чор таләпләреннән тыш, әхлакый-психол. яктан бәяләү омтылышы көчле (Х.Камаловның «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр», «Үлгәннән соң яздым» романнары һ.б.). Сугыш чорының «советча» яшәү рәвеше китереп чыгарган катлаулылыкларын яшермичә тасвирлаучы әсәрләр языла (М.Юнысның «Биектә калу», Н.Фәттахның «Кырык дүртенче елның май аенда» повестьлары). Документаль проза актив үсә башлый, Ш.Рәкыйпов, Р.Мостафин, Ә.Маликов — шушы юнәлешнең вәкилләре. Совет армиясенең югалтулары, әсирлеккә төшеп, сатлыкҗан дип нахакка рәнҗетелгән кешеләр язмышы хакындагы кырыс хакыйкатьне тасвирлаган очерк һәм хикәяләр, тыюларны җимереп, мемуар жанрын «уятып җибәрә». Шул ук вакытта рухи ярлылык прозаикларны халык рухының чишмә башына китерә. Халык тормышындагы төп кыйммәтләрне барлауга йөз тоткан «авыл прозасы»ның тууы һәм киң таралуы шуның б-н аңлатыла (А.Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар», Р.Төхфәтуллинның «Йолдызым» повестьлары). Халык яшәешен анализлау әдәбиятта милләт язмышы, туган җир проблемаларын алгы планга чыгара (Ә.Еникинең «Туган туфрак» хикәясе, Г.Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повесте). Туган җиргә багышланган әсәрләрдә күбрәк урынны үткәнне сагыну хисе били, алгы планга шәхси кичерешләр һәм мөнәсәбәтләр чыга, кысалы кыйссалар композициясе файдаланыла (М.Мәһдиевнең «Бәхилләшү», «Торналар төшкән җирдә», «Кеше китә, җыры кала» повестьлары). Алар «сентиментальреализм» билгеләре булып, тарихи үткәннәрнең образы хикәяләүченең шәхси истәлекләренә, ассоциацияләренә, лирик фикерләүгә нигезләнеп төзелә. Татар халкының милли фикерләү үзенчәлекләренә игътибар, милли характерын, традицияләрен сәнгатьчә тасвирлау совет чорын идеаллаштырудан баш тарту б-н үрелеп китә (Г.Бәшировның «Җидегән чишмә» романы). Т.п.нда тәнкыйть тенденцияләре көчәя (А.Гыйләҗев, Н.Фәттах, Ә.Баян, Хәсән Сарьян). Әхлакый мәсьәләләргә, замана җимеше булган үзенчәлекле социаль типлар тудыруга (Хәсән Сарьянның «Бер ананың биш улы» повесте), гади кешенең югары әхлагын, рухи матурлыгын күрсәтүгә (Г.Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр», А.Гыйләҗевнең «Урамнар артында яшел болын», А.Расихның «Ике буйдак» романнары) тартылу сизелә. А.Гыйләҗев әсәрләрендә («Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Өч аршын җир», «Җомга көн кич белән», «Әтәч менгән читәнгә» повестьлары) әхлаксызлыкның төп сәбәбе итеп кешенең үз тамырлары б-н рухи бәйләнешләрен югалтуы санала. Тарихи романның әхлакый асылы үзгәрүе б-н, Т.п.нда (Н.Фәттахның «Этил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар», М.Хәбибуллинның «Кубрат хан» романнары) милләтнең ерак тарихы һәм 20 йөз вакыйгаларын яңадан бәяләү башлана. Интеллектуаль тенденциянең психологизм б-н киселеше яңа рухи бөтенлек төзергә мөмкинлек бирә. Ул, үз чиратында, тормышның шатлыкларына һәм кайгыларына әзер, тарихи хәтергә, үткәннәргә һәм киләчәккә бәйле җаваплылык хисенә ия булган шәхескә кырыс таләпләр кую нәтиҗәсе санала (Ә.Еники, Ф.Хөсни, И.Гази, Г.Сабитов һ.б.). Халык тормышы күренешләрен производство темасына язылган романнарда (Г.Ахуновның «Хәзинә», Г.Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар», Ә.Баянның «Ут һәм су») һәм повестьларда (А.Гыйләҗевнең «Зәй энҗеләре» һ.б.) тергезү заманга хас күренешкә әверелә. Романтизмның (М.Галиевнең «Ак абагалар», «Алтын тотка» повестьлары) һәм сентиментализмның (М.Галиевның «Ерак урман авазы», Ф.Ярулинның «Кыйгак-кыйгак каз кычкыра» романнары һ.б.) кабат торгызылуы, «аң агышы»на мөрәҗәгать итү (Р.Вәлиевнең «Яшисе килә!», «Иске сәгать дөрес йөри», «Эт кояшы» повестьлары) авыл прозасының логик дәвамы итеп кабул ителә. Соц. рев-ция, шәхес культы (Г.Ахуновның «Идел кызы» дилогиясе, М.Хәсәновның «Язгы аҗаган» романы), кешелеккә янаган экологик һәлакәтләр (Г.Бәшировның «Җидегән чишмә» романы) нәтиҗәләрен яңадан шәрехләргә омтылып, өлкән буын прозаиклар зур формаларга мөрәҗәгать итәләр. Кешедәге җитешсезлекләрне, социаль кимчелекләрне тәнкыйтьләүнең нәтиҗәле чарасы булып юмор һәм сатира тора (Ф.Шәфигуллин, К.Кәримов, Ф.Баттал һ.б.).

20 йөз ахыры Т.п.ның үзенчәлеге реалистик, романтик, модернистик һәм постмодернистик стиль агымнарының янәшә яшәвеннән һәм кулланылуыннан үсеп чыга. Традицион проза күбесенчә социаль һәм әхлакый проблемаларга мөрәҗәгать итә (К.Кәримовның «Сакау күке», «Ком сәгате» романнары). Тоталитар үткәннәрне (Н.Фәттахның «Кичү» романы, Факил Сафинның «Саташып аткан таң» роман-трилогиясе, В.Имамовның «Тозлы яра» романы, З.Зәйнуллинның «Ат классы» повесте һ.б.) бәяләү вакытында социаль һәм экзистенциаль башлангычларның кушылуын тәэмин иткән шәхеснең коточкыч рухи җимерелүен (А.Гыйләҗевнең «Балта кем кулында?» романы), шәхес культы фаҗигаләрен (И.Салаховның «Колыма хикәяләре» повесте, А.Гыйләҗевнең «Йөгез, бер дога!» романы, Г.Тавлинның «Афәт» роман-трилогиясе, Р.Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» романы) тергезү «кырыс» реализм алымнарына таяна. Тарихи романнар (Р.Батулла, «Сөембикә»; Ф.Латыйфи, «Хыянәт»; М.Хәбибуллин, «Илчегә үлем юк», «Шайтан каласы», «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный»; Җ.Рәхимов, «Батырша»; В.Имамов, «Утлы дала»; Ф.Бәйрәмова, «Баһадиршаһ» һ.б.), халыкның ерак һәм якын үткәннәре турында уйландыру б-н беррәттән, кешене катып калган, аңа мәҗбүри тагылган фикерләрдән, татар халкының үткәненә

кагылышлы иллюзияләрдән азат итү омтылышы ягыннан аерылып торалар. Традицион реализм кысаларында советтан соңгы чорга (Т.Галиуллинның «Сәет Сакманов» трилогиясе, Р.Мөхәммәдиевнең «Кенәри — читлек кошы» романы, Г.Ахуновның «Этләр патшасы» повесте), тоталитар дәүләтнең милли сәясәтенә (Ф.Латыйфиның «Бәйсез этләрне атарга» повесте, Ф.Бәйрәмованың «Караболак» романы), соц. идеологиягә (Ф.Садриевның «Бәхетсезләр бәхете» трилогиясе) карата тискәре мөнәсәбәт белдергән әсәрләр туа. Үзгәртеп корулардан соңгы елларга бәйле ирония һәм сарказм З.Хәким иҗатындагы модернистик («Курку» повесте) һәм постмодернистик («Кишер басуы» повесте, «Агымсуда ни булмас» романы) юнәлешләрдә чагыла. Прозада файдаланылган мифологик фикерләү, кыйсса формасына тартылу җәмгыятьнең шартлы-метафорик моделен тудырырга, яхшылык, яманлык, тормыш мәгънәсе (Н.Гыйматдинованың «Китәм, димә» повесте, Г.Гыйльмановның «Албастылар» романы) кебек мәңгелек проблемаларны күтәрергә мөмкинлек бирә. Т.п.нда экзистенциаль-психол. (Ф.Садриевнең «Таң җиле», Ф.Латыйфинең «Ишелеп төшкән бәхет» романнары, Ф.Бәйрәмованың «Болын», «Битлек» повестьлары), фәлсәфи (Ф.Бәйрәмованың «Канатсыз акчарлаклар» повесте), интеллектуаль (Р.Сибатның «Ялгызак» романы), уен (Т.Миңнуллинның «Минһаҗ маҗаралары» романы) тенденцияләренең көчәюе иҗтимагый-әхлакый проблемаларның хакыйкатьне эзләү фәлсәфәсе б-н кушылуына китерә. Т.п. кысаларында төрле жанр сыйфатларының үзара тәэсире күзәтелә, нәфис публицистика (Ф.Яруллин, «Яралы язмышлар»), документалистика (А.Хәлим, «Сагыш китабы, яки Абориген язмалары», «Боза-боза паспортны, арттырабыз башкортны...»), гасырлар дәвамында сакланып килгән тарихи-фәлсәфи (М.Галиев), лирик-уйлануачан (Мөдәррис Вәлиев) һәм публицистик традицияләрне үз эченә алган эссе жанры активлаша. 1990 еллар уртасыннан дини әдәбият яңарыш кичерә (Ф.Бәйрәмованың «Алыплар илендә» повесте, «Соңгы намаз» романы). Анда иман һәм милләтнең киләчәге мәсьәләсе алгы планга чыга.

*Әд.:* З а һ и д у л л и н а Д.Ф. Модернизм һәм ХХ йөз башы татар прозасы. К., 2003; ш у л у к. Яңа дулкында (1980–2000 еллар прозасында традицияләр һәм яңачалык). К., 2006; История татарской литературы нового времени (ХIХ — начало ХХ века). К., 2003; Б р о й т м а н С.Н. Историческая поэтика. М., 2004; Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. К., 1984–2001.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**ТАТА́Р ПРОЛЕТА́Р ЯЗУЧЫЛАРЫ́ АССОЦИА́ЦИЯСЕ** (ТАПП), татар язучыларының иҗтимагый оешмасы. 1928 елда татар язучыларын берләштерү, әдәби хәрәкәтне активлаштыру максаты б-н Казанда оештырыла. Оештыручылары: К.Нәҗми, И.Гази, Г.Толымбайский, С.Каратай. Басма органы — «*Атака*» ж-лы (1930–32). Үзенең эшчәнлегендә ассоциация вульгар социологизм принципларына таяна, язучылар пролетар, крәстиян һәм «иярүчеләр»гә бүлеп карала, әдәби хәрәкәт «йә союздаш, йә дошман» лозунгы астында бара; әлеге кысаларга сыймаганнарга «эчке эмигрант», «кулак җырын җырлаучы» дигән ярлык тагыла; әдәби мәхкәмәләр оештырыла һ.б. ВКП(б) ҮКның 1932 ел 23 апрельдә чыккан «Әдәби оешмаларны үзгәртеп кору» карары нигезендә оешма таратыла.

*Н.Г.Гыйззәтуллин.*

**ТАТА́Р ПҮЧИНКӘСЕ́** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 12 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 80 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөз ахырында — 19 йөз башында нигез салына. 1860 ларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.П.ндә мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 307,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Никифоровка волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1859 да — 148, 1897 дә — 305, 1908 дә — 438, 1920 дә — 448, 1926 да — 490, 1938 дә — 433, 1949 да — 372, 1958 дә — 304, 1970 тә — 281, 1979 да — 216, 1989 да — 138, 2002 дә — 94 кеше.

**ТАТА́Р РАБФАГЫ́** (төрки-татар эшчеләр ф-ты), уку йорты. Казанда 1923 елда татар, башкорт, казакъларны югары уку йортына әзерләү өчен ачыла. Эшче-крәстиян балалары, кагыйдә буларак, башлангыч белеме һәм рус теленнән беренчел белеме булган ВЛКСМ һәм ВКП(б) әгъзалары кабул ителә; укучыларның якынча өчтән бере — кызлар. Уку вакыты 3–4 ел тәшкил итә (башка эшчеләр ф-тларына караганда 1–2 елга озаграк); нигездә, татар телендә укытыла торган гомуми белем фәннәреннән тыш, рус теле ныклап өйрәтелә. Ел саен якынча 30 кеше тәмамлый, яртысыннан күбрәге — Казанның югары уку йортларына, өчтән бере Мәскәү һәм Ленинград югары уку йортларына техник, а.х., пед. һәм гуманитар белгечлекләр буенча укырга керә. Т.р.н тәмамлаучылар арасында — булачак язучылар М.Җәлил, Г.Гобәй, С.Хәким, партия эшлеклесе З.И.Моратов, күп кенә атаклы журналистлар, инженерлар, дәүләт эшлеклеләре. 1923 тән – Казан укытучылар семинариясе бинасында, 1925 тән Казан Ксения (Икенче) кыз балалар гимназиясендә урнаша. 1929 да ябыла, укучылары Шәрекъ пед. ин-ты рабфагына күчерелә.

*Әд.:* Пять лет тюрко-татарского рабочего факультета. К., 1928; М о р о з о в а С.В. Деятельность Коммунистической партии по развитию рабочих факультетов в период строительства социализма (на материалах рабфаков Татарской АССР) // Уч. зап. Казан. гос. пед. ин-та. 1974. Вып. 139; М и н у л л и н Г. Татар рабфагы ачылуга 50 ел // Совет мәктәбе. 1973. № 11.

**ТАТА́Р РА́ТУШАСЫ**, к. *Казан шәһәре татар бистәләре ратушасы.*

**«ТАТА́Р РЕНЕ́ТЫ»**, алмагач сорты. 1952 елда Тәмте җиләк-җимеш станциясендә Г.И.Розанова тарафыннан «Ренет Поволжья» һәм «Боровинка» сортларын серкәләндерү юлы б-н чыгарыла. Салкынга чыдам, югары уңышлы, тиз җимеш бирүче (4–5 елдан җимеш бирә). Агачы уртача биеклектә, ябалдашы киң, түгәрәк, куе яфраклы, ботаклары нык, дугасыман бөгелгән, үрентеләре коңгырт төстә, аз төкле, вак ясмыкчыклар бар. Яфраклары зур түгел, түгәрәк, калын кабыклы, аз ялтыравыклы. Яфрак читләре каяу. Сабагының озынлыгы һәм киңлеге уртача. Чәчәкләре ак, касәсыман. Җимешләре уртача зурлыкта (70–100 *г*), түгәрәк, җиңелчә конуссыман, ачык яшел-саргылт төстә, сусыл җимшәнле, тәме әчкелтем-баллы; сентябрь уртасында өлгерә, декабрьгә кадәр саклана. 10 еллык агачы 120 *кг* га кадәр уңыш бирә. Бу сорт Татарстанда 1963 тә районлаштырыла.

*В.А.Наумов.*

**ТАТА́Р САПЛЫГЫ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 7 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 370 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 83%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1665–67 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашманлыкта эшли. 20 йөз башында Т.С.нда мәчет, 2 мәдрәсә, 5 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 753,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Яңа Кәкерле волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 394, 1897 дә — 707, 1913 тә — 819, 1920 дә — 812, 1926 да — 844, 1938 дә — 696, 1949 да — 592, 1958 дә — 399, 1970 тә — 196, 1979 да — 352, 1989 да — 316, 2002 дә — 353 кеше.

**ТАТА́Р САРАЛАНЫ́** авылы, Лаеш р-нында. Казан тимер юл станциясеннән 59 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычыннан 2 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 330 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1602–03 еллардан рус чыганакларында Саларань буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 2 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, тимерчелек, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире (Рус Сараланы авылын да кертеп) 2647 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Саралан волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 73 ир-ат; 1859 да — 845, 1897 дә — 1399, 1908 дә — 1635, 1920 дә — 1778, 1926 да — 1843, 1938 дә — 1619, 1949 да — 1118, 1958 дә — 1000, 1970 тә — 676, 1979 да — 514, 1989 да — 394, 2002 дә — 378 кеше.

**ТАТА́Р САРСАЗЫ́** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 22 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Чөмән елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 98 кеше (татарлар)

яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1680 нән рус чыганакларында Кече Чумень (Учумень) исеме б-н мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елларда авыл халкы Малмыж өязеннән күченүчеләр исәбенә арта. 1879 елгы мәгълүматларга караганда, ашлык саклау-сату кибете, 20 йөз башында мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 776,3 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1795 тә — 15 ир-ат; 1859 да — 145, 1887 дә — 231, 1905 тә — 297, 1920 дә — 729, 1926 да — 754, 1938 дә — 769, 1949 да — 599, 1958 дә — 540, 1970 тә — 315, 1979 да — 211, 1989 да — 133, 2002 дә — 116 кеше.

**ТАТА́Р САРСАЗЫ́** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 19 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 469 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.С.нда мәчет (1890 да төзелә), мәдрәсә, җил тегермәне, ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1579 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Изгар волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 61 ир-ат; 1859 да — 745, 1897 дә — 904, 1908 дә — 1058, 1920 дә — 1159, 1926 да — 944, 1938 дә — 782, 1949 да — 498, 1958 дә — 511, 1970 тә — 444, 1979 да — 315, 1989 да — 481, 2002 дә — 538 кеше.

**ТАТА́Р СӘНГА́ТЬ ЭШЧЕ́ ТЕА́ТРЫ**, д ә ү л ә т  к а р а м а г ы н д а. 1930 елда Казанның Киров р-нында Елга аръягы Эшчеләр сарае каршында, цехларда эшләүче эшчеләр коллективларына өйлә вакытында хезмәт күрсәтү максатыннан, кечкенә формалы театр буларак оеша. 8–10 һәвәскәр артисттан тора; репертуарын скетчлар, көнүзәк җитештерү темасына зур булмаган сәхнә күренешләре тәшкил итә. 1932 дә — партиянең «Авиастрой» төзелеш ком-ты, 1933 тән ТАССР Мәгариф халык комис-ты карамагына күчә һәм рәсми рәвештә «Татар дәүләт сәнгать күчмә эшче театры» дип аталып йөртелә башлый. Сәнгать җитәкчесе һәм директоры итеп Ә.Г.Мәҗитов билгеләнә. 1935 тә театрга Печән базары мәчете бинасын бирәләр. Труппа составында һәвәскәр актёрлар һәм Татар театр техникумын тәмамлаучылар Ч.Аджарова, Ж.Вәлиев, В.Гафаров, И.Гафуров, К.Гыйльманов, Р.Гобәйдуллина, А.Заһидуллин (Мамай), Ш.Зарипов, Ф.Зарипова, Н.Камалов, М.Карамышева, С.Сәгыйтов, Г.Сәлахов, Г.Ситдыйков, Ф.Халитов, А.Хәсәнов, Ш.Шакиров була. Репертуарын Ә.Мәҗитовның «Гармун сөйләр», «Кыю куркак», «Көяшлы цех», «Уңышсыз карьера», «Шәхси секретарь», Г.Камалның «Беренче театр», Ш.Камалның «Ут», Ф.Вольфның «Каттаро матрослары» («Матросы из Каттаро») пьесалары тәшкил итә. Эшчәнлегенең башлангыч чорында театрның иҗат ысулы спектакльләрдәге актуаль сәяси проблемаларны яктыртуга нигезләнә; актёрлардан теге яки бу рольне башкаруда җиңеллек, тәэсирлелек, сәнгатьлелек, плакатлылык, текстны ачык итеп җиткерү таләп ителә. Алга таба зур күләмле драматургия материалы б-н эш иткәндә, проф. режиссёрларны (С.Я.Вәлиев-Сульва, Б.Э.Ниренбург), сәхнә теле һәм актёрлык осталыгы буенча педагогларны чакырып ала башлыйлар, проф. белем бирү оештырыла. Үз бинасы эшкә яраклы булмау сәбәпле, актёрлар шәһәрнең клуб мәйданчыкларында, пр-тиеләр цехларында чыгыш ясарга, ТАССР районнары буйлап гастрольләрдә йөрергә мәҗбүр булалар; 1934 нең җәендә театр ике тапкыр Мәскәүгә гастрольгә чыга. 1937 дә матди базасы булмау сәбәпле ябыла.

*Ю.А.Благов.*

**ТАТА́Р СМЫ́ЛОВКАСЫ** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 19 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Башкортстан Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 18 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 19 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Смыловка исеме б-н мәгълүм. 1861 гә кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, поташ з-ды, 20 йөз башында ашлык саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 34 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Карамалы волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 41, 1920 дә — 89, 1926 да — 161, 1938 дә — 144, 1949 да — 145, 1958 дә — 137, 1970 тә — 93, 1979 да — 58, 1989 да — 76, 2002 дә — 39 кеше.

**ТАТА́Р СОВЕ́Т СОЦИАЛИ́СТИК РЕСПУ́БЛИКАСЫ**, к. *Татарстан Республикасы.*

**ТАТА́Р СОВЕ́Т ЯЗУЧЫЛАРЫ́ ОЕШМАСЫ́**, иҗади проф. берләшмә. Вакытлы матбугатта аны оештыруның һәм эшчәнлегенең принциплары хакында актив фикер алышу бара (Г.Нигъмәти, Г.Ибраһимов, Гомәр Гали мәкаләләре). КПСС өлкә ком-тының матбугат бүлеге каршында оештырылган әзерләү комиссиясенә Г.Ибраһимов, Ф.Бурнаш, Г.Толымбай, Г.Нигъмәти керә. 1928 елның маенда язучылар җыелышы яңа оешма төзелүен игълан итә. Аның бюросына Г.Нигъмәти, Ф.Сәйфи-Казанлы, Г.Толымбайский, Г.Кутуй, К.Тинчурин сайлана. Оешманың максатлары: язучыларның проф. осталыгын камилләштерү, марксизм позицияләреннән чыгып әдәби процесс б-н җитәкчелек итү, буржуаз милләтчелек идеологиясенә каршы көрәш алып бару. Моңа кадәр яшәп килгән әдәби түгәрәкләр һәм оешмалардан («Завод», «Часовой», «Октябрь», «Сулф») аермалы буларак, Т.с.я.о.на татар телендә язучылар гына түгел, ТАССРда яшәгән башка халыклар телләрендә язучылар да керергә хокуклы була. Оешманың матбугат органы — «Яңалиф» ж-лы. *Татар пролетар язучылары ассоциациясе* (ТАПП) б-н тыгыз бәйләнештә була. ВКП(б) ҮКның «Әдәбият һәм сәнгать оешмаларын яңабаштан үзгәртеп кору турындагы» 1932 ел 23 апрель карары нигезендә таратыла.

*Әд.:* Г ы й з з ә т у л л и н Н. Әдәби оешмалардан — бердәм союзга // Казан утлары. 1984. № 7.

*Н.Г.Гыйззәтуллин.*

**ТАТА́Р СОЦИА́Л-ДЕМОКРА́Т ЭШЧЕЛӘ́Р ПА́РТИЯСЕ СЪЕЗДЫ́**, 1917 елның 15 октябрендә Уфа шәһәрендә ачыла. *«Алга»* г-тасы редакциясе тирәсенә берләшкән татар-башкорт төркеме тарафыннан чакырыла. Съезд президиумы составына РКП(б)ның Уфа ком-ты әгъзалары Б.Нуриманов (рәис), З.Габиев (рәис иптәше, Троицк ш.), Ә.Хәбиби (сәркәтип, Уфа) керә. Съездның көн тәртибе: 1) Татар с.-д. эшчеләр партиясен оештыру; 2) программа һәм устав кабул итү; 3) Үзәк башкарма ком-ты сайлау; 4) финанс мәсьәләсе; 5) партиянең басма органы турында; 6) милли-мәдәни оешма турында; 7) Учредительләр җыены турында; 8) сугыш турында; 9) хакимияткә карата мөнәсәбәт турында. Съездда *Татар социал-демократ эшчеләр партиясе* оешуы турында игълан ителә; нигез итеп татар теленә тәрҗемәдә РСДРПның программасы һәм уставы кабул ителә, дәүләт составына керүче халыкларның үзбилгеләнү мәсьәләсенә кагылышлы параграфы хуплана. Партиянең 6 кешедән торган Вакытлы үзәк башкарма ком-ты сайлана (Б.Нуриманов, К.Кәбиров, Ф.Әхмәдуллин, Уфа; Г.Шәмигулов, Чиләбе ш.; Троицк һәм Екатеринбург шәһәре вәкилләре өчен 2 урын калдырыла). Партиянең басма органы — «Алга» г-тасы. Съезд Учредительләр җыенындагы сайлауларда с.-д. интернационалистлар һәм большевиклар исемлеге өчен тавыш бирергә дигән карар кабул итә; империалистик сугышны гаепли, хакимият мәсьәләсендә «Хакимият Советларга» лозунгына кушыла.

*Р.Г.Хәйретдинов.*

**ТАТА́Р СӨНЧӘЛЕСЕ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 16 *км* көньяк-көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 364 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1700 гә кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.С.ндә мәчет, су тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1889 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан

губернасының Чистай өязе Иске Мукшы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 47 ир-ат; 1859 да — 752, 1897 дә — 1279, 1908 дә — 1501, 1920 дә — 1378, 1926 да — 882, 1938 дә — 1025, 1949 да — 692, 1958 дә — 629, 1970 тә — 754, 1979 да — 612, 1989 да — 412, 2002 дә — 376 кеше.

**ТАТА́Р СПАСЫ́**, *Болгар* шәһәренең 1926–35 еллардагы атамасы.

**ТАТА́Р СУЫКСУЫ́** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 28 *км* көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 855 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1745 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Башкорт Суыксуы исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.С.нда волость идарәсе, почта станциясе урнаша; мәчет (1798 дән билгеле), мәктәп, җил һәм су тегермәне, базар эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3035,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 197, 1834 тә — 431, 1859 да — 546, 1870 тә — 632, 1884 тә — 599, 1897 дә — 778, 1906 да — 972, 1913 тә — 929, 1920 дә — 983, 1926 да — 1041, 1938 дә — 922, 1949 да — 822, 1958 дә — 883, 1970 тә — 909, 1979 да — 988, 1989 да — 936, 2002 дә — 875 кеше.

**ТАТА́Р СУЫКСУЫ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 14 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 103 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Китапханә. Мәчет. 1670–80 елларда нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.С.нда мәчет, мәдрәсә, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1668 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Әлки волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 120 ир-ат; 1859 да — 703, 1897 дә — 1086, 1908 дә — 1289, 1920 дә — 1199, 1926 да — 685, 1938 дә — 498, 1949 да — 326, 1958 дә — 388, 1970 тә — 310, 1979 да — 230, 1989 да — 120, 2002 дә — 109 кеше.

**ТАТА́Р ТАКТАЛЫСЫ́** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 45 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Такталы елгасы буенда. 2010 елда 297 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1716–17 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек һәм тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Т.нда мәчет, мәдрәсә, рус-татар уч-щесе (1911 дә ачыла), җил тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1074,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Гусиха волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 8 ир-ат; 1859 да — 430, 1897 дә — 695, 1908 дә — 885, 1920 дә — 879, 1926 да — 486, 1938 дә — 581, 1949 да — 531, 1958 дә — 611, 1970 тә — 696, 1979 да — 484, 1989 да — 348, 2002 дә — 333 кеше.

**ТАТА́Р ТАЛКЫШЫ́** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 18 *км* көньяктарак, Талкыш елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 482 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, 2 мәчет. 1710 елларда нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Т.нда 5 мәчет (1843, 1871, 1898, 1912, 1913 тә төзелә), мәдрәсә, 7 тегермән, 2 ярма яргыч, 13 вак-төякләр кибете эшли; этап йорты урнаша. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 5256 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Мөслим волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 178 ир-ат; 1859 да — 2160, 1897 дә — 3071, 1908 дә — 3122, 1920 дә — 3216, 1926 да — 2684, 1958 дә — 1524, 1970 тә — 754, 1979 да — 637, 1989 да — 499, 2002 дә — 528 кеше.

**ТАТА́Р ТАНАЕ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 46 *км* көньяк-көнбатыштарак, Гөбенә елгасы буенда. 2010 елда 446 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1619 дан рус чыганакларында Мамадыш Тавгильдеева исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәдрәсә, су һәм җил тегермәне, 2 ярма яргыч, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1324,95 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 104 ир-ат; 1859 да — 621, 1897 дә — 1293, 1908 дә — 1604, 1920 дә — 1369, 1926 да — 1113, 1938 дә — 1149, 1949 да — 844, 1958 дә — 646, 1970 тә — 700, 1979 да — 631, 1989 да — 523, 2002 дә — 507 кеше.

Т.Т.нда язучы А.Ш.Шамов туган.

**ТАТА́Р ТАҢСАРЫ́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 35 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сарсак елгасы буенда. 2010 елда 39 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, иткә терлек асрау. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Даташуран исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чыпта-кап сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 370 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Зур Кибә волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1763 тә — 28, 1859 да — 120, 1887 дә — 127, 1905 тә — 176, 1920 дә — 246, 1926 да — 257, 1938 дә — 295, 1958 дә — 173, 1970 тә — 152, 1989 да — 92, 2002 дә — 48 кеше.

**ТАТА́Р ТӘКӘШЕ́** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 11 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 85 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 нән рус чыганакларында Починок по речке Кусянде исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп (1908 дә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 434,3 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1795 тә — 28 ир-ат; 1859 да — 110, 1887 дә — 201, 1905 тә — 277, 1911 дә — 305, 1920 дә — 333, 1926 да — 336 (1920 һәм 1926 елгы мәгълүматлар Мари Тәкәше авылы халкын да кертеп бирелә), 1938 дә — 294, 1949 да — 240, 1958 дә — 182, 1970 тә — 190, 1979 да — 150, 1989 да — 89, 2002 дә — 80 кеше.

**ТАТА́Р ТЕЛЕ́**, татар халкының барлык этнотерр. төркемнәре (Идел-Урал буе, Себер, Кырым, Добруджа һ.б.) теле. *Төрки телләрнең* болгар-кыпчак төркеменә керә. ТРда, Башкортстанның шактый районнарында, Мари, Удмурт, Мордва Респ-каларында, Россиянең күпчелек өлкәләрендә, ш.у. Үзбәкстан, Казакъстан, Әзәрбайҗан, Кыргызстан, Таҗикстан, Төрекмәнстан Респ-каларының аерым районнарында киң таралыш ала. Россиядә якынча 4,3 млн. кеше (2010 елгы халык санын исәпкә алу буенча) Т.т.ндә сөйләшә. Т.т.нең диалект системасы өч терр. диалекттан гыйбарәт: *урта диалект, мишәр* (көнбатыш) *диалекты* һәм *көнчыгыш диалект* (Се-

бер татарлары шивәсе җыелмасы). Хәзерге татар әдәби теле 19 йөзнең 2 нче яртысында *иске татар әдәби теле* б-н *койне* нигезендә формалаша. Иске татар әдәби теле — иске төрки әдәби телгә, анысы исә борынгы төрки язма әдәби телгә барып тоташа. Борынгы төрки тел — рун язулы текстларда (к. *Борынгы төрки рун язуы*), иске төрки һәм иске татар телләре гарәп графикасындагы текстларда теркәлеп калган. Хәзерге татар әдәби теле иң элек гарәп графикасында була. 1927 дә — *латин язуы* (к. *Яңалиф*) нигезендә, 1939 да — *кириллицага* нигезләнеп, Т.т.ндәге үзенчәлекле авазларны белдерү өчен ә, ө, ү, җ, ң хәрефләре (алар алфавит ахырына урнаштырыла) өстәлеп, Т.т.нең *алфавиты* кабул ителә. Т.т.ндә 10 төп сузык фонема бар, аларның берсе — [ый] фонемасы дифтонгка якын, 3 есе — [о], [ы], [е] рус алынмаларында кулланыла (к. *Вокализм*). 26 төп тартык аваз һәм алынма сүзләрдә кулланыла торган 5 — [ц], [щ], [тч], [х'], [в] фонемалары бар. Соңгысы инглиз телендәге [w] авазына охшаган элеккеге ирен-ирен [в] авазыннан аерыла. Үзенчәлекле увуляр [к], [ғ], фарингаль [h] һәм ларингаль ['] (һәмзә) авазларын белдерүче махсус хәрефләр юк, алар төрлечә билгеләргә мөмкин (к. *Тартык авазлар*). Т.т.ндә род категориясе юк, фигыльнең синтетик формалары б-н беррәттән аналитик заман формалары да киң кулланыла; ярдәмче фигыльләр хәрәкәт ысулын, аның ешлыгын, төгәлләнү дәрәҗәсен һ.б. белдерә. Синтетик иярчен җөмләләрнең төрләре күп, еш кына *изафә* кулланыла.

Т.т. *агглютинатив телләргә* керә, *сингармонизм* законына буйсына. Лексикасында саф төрки һәм татар сүзләреннән тыш *гарәп алынмалары, фарсы алынмалары, рус алынмалары, интернациональ сүзләр* зур урын алып тора. Т.т. рус теле б-н беррәттән ТРның дәүләт теле санала («Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» ТР законы, 1992).

Татар телен фәнни нигездә өйрәнә башлау М.Котельниковның русча-татарча сөйләүлегенә (1740), С.Хәлфиннең «Татар теле әлифбасы» («Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов», М., 1778) һәм «Русча-татарча сүзлек» (1785) хезмәтләренә бәйләп карала. 1801 дә С.-Петербургта — Т.т. грамматикасы, 1804 тә И.Гигановның «Йорт (юрт) муллалары тарафыннан расланган ... Россия-татар сүзлеге» («Словарь российско-татарский ... муллами юртовскими свидетельствованный») нәшер ителә. 1830–40 елларда Казан ун-тының *Шәрекъ бүлегендә* Казан тюркологлар мәктәбе оеша. Аның составында И.Хәлфин, М.Казимбәк, И.Н.Березин, М.Мәхмүдов, К.Насыйри, Ә.Ваһапов һ.б. була. Т.т.н өйрәнүгә Г.Х.Алпаров, В.А.Богородицкий, М.З.Зәкиев, Ф.С.Сафиуллина, Ф.Ә.Ганиев, Д.Г.Тумашева, В.Х.Хаков, Ф.М.Хисамова һ.б. зур өлеш кертә. Т.т. буенча тикшеренүләр Казан ун-тында, Татар гуманитар-пед. ун-тында, ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында, Алабуга һәм Чаллы пед. ин-тларында, Башкорт дәүләт, Мәскәү пед., Төмән ун-тларында, Башкорт, Тубыл, Бөре, Оренбург пед. ин-тларында, Эстәрлетамак пед. академиясендә алып барыла. Хәзерге татар әдәби теленең фонетик һәм грамматик төзелеше «Татар грамматикасы»нда (1–3 т., 1998–2002) тулы тасвирлана. Татар теленең аңлатмалы сүзлекләрендә («Татар теленең аңлатмалы сүзлеге», 1–3 т., 1977–81; «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге», 2005; Ф.Ә.Ганиев ред.) аның 19 йөз ахыры — 20 йөз дәвамында фольклор әсәрләрендә, әдәби, фәнни һәм публицистик әдәбиятта, вакытлы матбугатта беркетелеп калган сүзлек һәм фразеологик фонды чагылыш таба.

*Әд.:* Якупова Г.К. Библиография по татарскому языкознанию. К., 1988; Закиев М.З. Татарский язык // Государственные языки в Российской Федерации. М., 1995; Письменные языки мира: Языки Российской Федерации. М., 2000; Казанская лингвистическая школа. К., 2008. Кн. 1; Народы России: Энцикл. М., 1994.

*М.З.Зәкиев.*

**ТАТА́Р ТЕЛЕ́Н ГАМӘЛГӘ́ КЕРТҮ́ (ТТГК) КОМИ́ССИЯСЕ**, ТАССР ҮБК каршында аның бүлеге хокукында төзелгән махсус орган. ТАССР БҮБК һәм ХКСның татар телен респ-каның совет учреждениеләрендә эш теле буларак гамәлгә кертү турындагы 1921 ел 25 июнь Декреты нигезендә оеша. Комиссиягә «...барлык татар мәдәни көчләрен барлап һәм Үзәктә, ш.у. урыннарда билгеләп кую юлы б-н» алардан файдалану һәм саклау бурычы йөкләнә. Шуңа охшаш эшне оештыру өчен, ТАССР ҮБКның 1922 ел 13 май карары нигезендә барлык кантон ком-тлары каршында 5 кешедән (кантон башкарма ком-ты вәкиле, ТАССР Юстиция халык комис-тының вәкаләтле вәкиле һ.б. оешмалардан вәкилләр) торган ТТГК комиссияләре төзергә кирәклеге хәл ителә. Әлеге комиссияләр чыгарган карарларның тиешле дәүләт учреждениеләре тарафыннан үтәлүе мәҗбүри була. Башта эш кәгазьләрен татар телендә алып бару хокукыннан файдалану җәмәгать кооперативлары һәм һөнәри оешмаларның үз ихтыярына куела. Шулай булса да, ТТГК эшенең үсеш дәрәҗәсеннән чыгып, ТАССР ҮБКның 1924 ел 30 апрель карары б-н эш кәгазьләрен татар һәм рус телләрендә алып бару мәсьәләләре буенча алда кабул ителгән карарлар аларга да кагыла. ТТГК комиссияләренең эш программасы гаять зур була, ТАССР Мәгариф халык комис-ты аеруча мөһим чараларны гамәлгә ашыручы төп дәүләт органы булып тора. Ул эш кәгазьләре орфографиясе мәсьәләләрен хәл итәргә, почта-телеграф аша хәбәрләшү өчен татар телендә терминнар сүзлеген эшләргә тиеш була, аңа ш.у. дәүләт органнары һәм элемтә учреждениеләренең татарча белмәгән хезмәткәрләре өчен татар теле курслары оештыру, татар телен өйрәнергә теләүчеләр өчен 2 нче баскыч рус мәктәпләрендә — татар теле, татар мәктәпләрендә рус теле укытуны гамәлгә кертү эшләре дә йөкләнә. ТАССР Мәгариф халык комис-ты 1921–22 еллардагы ачлык вакытында ябылган татар мәктәпләре эшчәнлеген торгызу буенча да чаралар күрергә һәм «татар халык театрларын актив үстерергә» тиеш була.

Декрет кичектергесез рәвештә телеграф конторaларына телеграммаларны рус хәрефләре б-н татар телендә кабул итә һәм җибәрә башларга куша. Ул ш.у. ҮБК һәм ТАССР Юстиция халык комис-тына кичекмәстән татар халкы күпләп урнашкан җирләрдә хөкем процессы хөкем ителүченең туган телендә алып барыла торган (зарурлык туганда, тәрҗемәчеләрне дә җәлеп итеп) халык судлары оештыруны йөкли.

ҮБК, ХКС һ.б. дәүләт учреждениеләренең барлык декретлары һәм карарлары татар һәм рус телләрендә басылырга тиешлеге билгеләнә. Теге яки бу учреждение һәм пр-тиеләрнең мөһерләре, элмә такталары бөтен җирдә дә шушы ике телдә эшләнергә тиеш була. Хатлар һәм эш кәгазьләрен ике телдә алып баруда кыенлыклар кичергән идарә органнарына өч кешегә кадәр штат б-н «тәрҗемәчеләр бюросы» оештыру рөхсәт ителә.

Дәүләт органнарының ТТГК мәсьәләләре буенча карарларын тормышка ашыру барышын тикшерү өчен даими контроль булдырыла. 1924 нең апрелендә РКП(б) Татарстан өлкә ком-ты пленумының киңәйтелгән утырышында Үзәк комиссиянең ТТГК буенча доклады тыңлана; шул ук елның сентябрендә бу мәсьәлә кантоннарның башкарма ком-тлары киңәшмәсендә дә тикшерелә; 1925 тә әлеге эшнең нәтиҗәләре һәм якын киләчәккә перспективалар ТАССР ҮБК сессиясендә карала.

1925 нең гыйнварында ТАССР ҮБК Президиумы «ТАССРда татар телен гамәлгә кертүнең перспективалы планы»н раслый, аның нигезендә 1930 га респ-каның барлык учреждениеләре, пр-тие һәм оешмаларындагы эш кәгазьләрендә татар һәм рус телләренең тулы һәм фактик тигез хокуклылыгын гамәлгә ашыру күздә тотыла. Әлеге масштаблы эшне оештыруга ТТГК комиссиясенең беренче рәисе, 1921–24 тә ТАССР ҮБК Президиумы рәисе Р.Ә.Сабиров, 1924–27 дә шушы вазифаны башкарган Ш.Ш.Шәймәрданов, ТАССР ХКС рәисе К.Г.Мохтаров, ТТГК комиссиясе рәисе урынбасары А.Г.Ганиев, әлеге комиссиянең секретаре Г.Ш.Шәрәф, ТАССР ҮБК әгъзасы Ф.З.Бурнаш һ.б. зур өлеш кертәләр. 1920 еллар ахырына, илдә тоталитар режим көчәю сәбәпле, ТТГК эшләре йомшара төшә. Шулай да 1921 нең 25 июнендә ТАССР БҮБК һәм ХКС Декреты кабул ителгәннән соңгы вакыт эчендә татар теле төрле учреждениеләрдә дәүләт теле функцияләрен үти башлый; татар телен белүче хезмәткәрләр саны арта, ул эш кәгазьләрендә файдаланыла башлый; җинаять-процессуаль, җир һәм хезмәт кодекслары татар теленә тәрҗемә ителә; мәктәпләрдә, һөнәри техник уч-щеләрдә, эшчеләр ф-тларында татар телен укыту кертелә.

Чыг.: Сборник декретов, постановлений, важнейших циркуляров и других материалов в области реализации татарского языка. К., 1925.

*Әд.:* Климов И.М. Образование и развитие Татарской АССР. 1920–1926 гг. К., 1960; Сайдашева М.А. К истории формирования татарской социалистической интеллигенции // Великий Октябрь и некоторые вопросы формирования татарской социалистической нации. К., 1989.

*Г.С.Сабирҗанов, З.Г.Гарипова.*

**ТАТА́Р ТОЛЛЫСЫ́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 38 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Консар елгасы буенда. 2010 елда 416 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. Мәчет. 1680 нән рус чыганакларында Пустошь по речке Тулле исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, тегермән, ярма яргыч, 2 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 676,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Лыябаш-Келәүш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 февраленнән — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 29 ир-ат; 1859 да — 279, 1897 дә — 519, 1908 дә — 565, 1920 дә — 627, 1926 да — 575, 1949 да — 420, 1958 дә — 419, 1970 тә — 514, 1979 да — 466, 1989 да — 446, 2002 дә — 441 кеше.

**ТАТА́Р ТОМБАРЛЫСЫ́** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 10 *км* көньяктарак, Томбарлы елгасы буенда. 2010 елда 672 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Миңлегол, Узлы исемнәре б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, земство станциясе, 3 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3050 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Баулы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1816 да — 146 ир-ат; 1859 да — 541, 1889 да — 805, 1897 дә — 1061, 1910 да — 1729, 1926 да — 1361, 1938 дә — 912, 1949 да — 769, 1958 дә — 842, 1970 тә — 781, 1979 да — 648, 1989 да — 495, 2002 дә — 662 кеше.

**ТАТА́Р ТӨГӘЛБАЕ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 22 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бизнә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 169 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1640–50 елларда нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Т.нда 2 мәчет, мәдрәсә, 3 җил тегермәне, 3 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3964,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Кузнечиха волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 132 ир-ат; 1859 да — 956, 1897 дә — 1487, 1908 дә — 1684, 1920 дә — 1679, 1926 да — 826, 1938 дә — 668, 1949 да — 592, 1958 дә — 618, 1970 тә — 707, 1979 да — 575, 1989 да — 311, 2002 дә — 262 кеше.

**ТАТА́Р ТӨКЕСЕ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 21 *км* төньяк-көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 200 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1665–67 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашманлыкта эшли; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Т.ндә мәчет, мәдрәсә, 5 сәүдә-сәнәгать йорты була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 839,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Мөчәли волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 330, 1897 дә — 547, 1913 тә — 872, 1920 дә — 740, 1926 да — 797, 1938 дә — 827, 1949 да — 844, 1958 дә — 856, 1970 тә — 891, 1979 да — 686, 1989 да — 363, 2002 дә — 255 кеше.

Т.Т.ндә шагыйрь З.Ш.Нури туган.

**«ТАТА́Р ТӨРКЕМЕ́»**, 1904–06 елларда татар яшьләренең Казандагы яшерен иҗтимагый-сәяси оешмасы. Җитәкчесе — РСДРП әгъзасы И.*Әхтәмов*. Оешманың үзәген шәкертләр һәм татар мәдрәсәләрен тәмамлаучылар Ф.Әмирхан, С.Әхмәров, М.Бәдигый, И.Бикколов, И.Камалов, Г.Мостафин, З.Садыйков тәшкил итә. Төркем революцион эчтәлекле прокламацияләр язып татар халкы (эшчеләр, вак һөнәрчеләр, приказчиклар, укучы яшьләр) арасында тарата; сәяси эшчәнлек б-н мәдәни-агарту эшләрен бергә алып бара. Мәс., Казанда 1906 ның маенда «Т.т.» башлангычы б-н беренчеләрдән булып халык алдында татарча спектакль куела.

**ТАТА́Р УЛАННАРЫ́ ПОЛКЫ́,** М.Ахматович исемендә, Польша армиясе составындагы кавалерия часте. 1919 елда 1 нче татар эскадроны буларак оештырыла. 1920 дә М.Ахматович исем. татар уланнары полкы дип атала. Полк, башлыча, Польша-Литва татарларыннан һәм Кавказ, Әзәрбайҗан мөселман халыкларыннан туплана. Командирлары — генерал А.Р.*Романович*, подполковник З.Крычиньский. 1920 дә Совет-Польша сугышы вакытында Киевны яулап алуда катнаша. 1920 нең июнендә Польша гаскәрләре чигенгәндә полк җиңелә, аларның саны 90 кешегә кадәр кими. Варшава янындагы сугыштан соң 1920 нең августында полк таратыла. 1920 нең сентябрендә калган сугышчыларыннан Мөселман дивизионы (командир-ротмистр Дацкевич) оештырыла, 1921 дә яңадан эскадронга үзгәртелә.

*Әд.:* Tatarski pulk ulanow. Gdansk-Bialystok, 1990.

*Я.Я.Гришин.*

**ТАТА́Р УРМАТЫ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 31 *км* көнчыгыштарак, Урмат елгасы буенда. 2010 елда 73 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1602–03 тән Урмат исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Урмат буларак та мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1909 да төзелә), мәктәп, 2 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 511 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 37 ир-ат; 1859 да — 235, 1897 дә — 327, 1913 тә — 366, 1920 дә — 437, 1926 да — 172, 1938 дә — 223, 1970 тә — 128, 1979 да — 96, 1989 да — 63, 2002 дә — 50 кеше.

**«ТАТА́Р УЧАГЫ́»**, 1915–17 елларда Петроградта татар студентлары түгәрәге. Җитәкчеләре: И.*Алкин* (Политехник ин-т) һәм Г.*Шәрәф* (Юл ин-ты), әгъзалары: Ә. һәм Г.Абызовлар, Җ.Алкин, Ш.Максутова, С.Мамлиев, С.Рахманкулов, К.Сәгыйт, С.Якубов һ.б. Түгәрәккә йөрүчеләр әдәби һәм фәнни әдәбият өйрәнәләр, Г.*Исхакый* тәкъдиме б-н аларны татар теленнән рус теленә тәрҗемә итәләр, спектакльләр куялар (Петроградның мөселман хәйрия җәмгыятендә). Эчке Россия, Себер һәм Кавказ мөселманнарының милли дәүләтләрен төзү мәсьәләләрен тикшерәләр, татар халкының сәяси һәм мәдәни мөстәкыйльлеген, татар теле үсешен яклап чыгалар. Катнашучыларның күбесен армиягә алганнан соң, түгәрәк эшчәнлегенең активлыгы сүрелә, 1917 дә «Т.у.» тарала. Соңыннан түгәрәк әгъзалары 1917 елгы революция вакыйгаларында, татар милли хәрәкәтендә, татар мәдәнияте үсеш юлларын билгеләү дискуссияләрендә актив катнашалар.

*Әд.:* Валеев Р.К. Признаю себя невиновным. К., 2007; Ислам в Санкт-Петербурге: Энцикл. словарь. М.-Н.Новгород, 2009.

*Р.К.Вәлиев.*

**ТАТА́Р ҮБИЕ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Чынлы елгасы буенда. 2010 елда 51 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Мәчет. 1723 кә кадәр нигез салына. 1720 еллардан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–1860 елларда Удел ведомствосы карамагында; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Ү.ндә мәчет, мәдрәсә, поташ з-ды, 4 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 586,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Үби волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 197, 1897 дә — 318, 1913 тә — 476, 1920 дә — 408, 1926 да — 382, 1938 дә —

377, 1949 да — 269, 1958 дә — 190, 1970 тә — 332, 1979 да — 173, 1989 да — 74, 2002 дә — 68 кеше.

Т.Ү.ндә актёр Һ.И.Солтанов туган.

**ТАТА́Р ФИЛАРМО́НИЯСЕ** (Г.Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе), концертлар оештыру, ТАССРның иҗади ресурсларын бергә туплау, дөнья муз. мирасын һәм респ-каның муз. культурасын пропагандалау максаты б-н 1937 елда оеша. 1946 да Г.Тукай исеме бирелә. Т.ф.нең беренче муз. коллективлары — симф. оркестр (1939 дан Татар опера һәм балет театрына бирелә, 1966–2007 дә яңадан Т.ф. составында), Татар халык музыка уен кораллары оркестры (сәнгать җитәкчесе А.С.Ключарёв; 1941 дә таркала), Дәүләт хор капелласы (сәнгать җитәкчесе И.Грекулов; 1938 гә кадәр эшли), Җыр



Г.Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе.

һәм бию ансамбле (хәзер Татарстан Респ-касының дәүләт җыр һәм бию ансамбле, 1991 гә кадәр филармония составында). 1937 дә Т.ф. каршында татар фольклоры кабинеты һәм эстрада-концерт бүлеге (1942 дә муз.-әдәби лекторий һәм эстрада бүлегенә аерыла) ачыла. Муз.-әдәби лекторийның төп бурычы киң катлау халык арасында дөнья һәм татар музыкасы һәм әдәбиятын пропагандалау була. Төрле елларда Т.ф. составында камера инструменталь һәм вокаль коллективлары эшли; Татарстанның атаклы сәнгать эшлеклеләре чыгышлары, респ-кадан читтә яшәүче мәшһүр музыкантлар һ.б. татар артистларының гастрольләре оештырыла. Т.ф.ндә эшләгән яисә аның эшчәнлегенә җәлеп ителгән артистлар — гармунчылар Ф.Биккинин, Г.Җәмлиханов, Ф.Туишев; җырчылар Р.Тимерханова, В.Шәрипова, И.Шакиров, Ә.Авзалова, Н.Теркулова, А.Арсланов, В.Гыйззәтуллина, Э.Җәләлетдинов, Г.Ильясов, З.Нурмөхәммәтов, Р.Ибраһимова, Н.Василова, Х.Тимергалиева һ.б. Озак вакыт дәвамында Т.ф. вакытлыча файдалануга бирелгән концерт мәйданчыкларына гына ия була. 2000 дә үзенең концерт залын булдыруга ирешә. Хәзерге вакытта Т.ф. каршында Татарстан Респ-касының Дәүләт халык музыка уен кораллары оркестры (1993 тән; сәнгать җитәкчесе А.И.Шутиков), Татарстан Респ-касының Дәүләт фольклор музыкасы ансамбле (1999 дан; сәнгать җитәкчесе А.Ф.Фәйзрахманов), Татарстан Респ-касының Дәүләт филармония джаз-оркестры (2011 дән; сәнгать җитәкчесе А.А.Василевский), классик муз. мирасны, заманча музыканы, татар халык һәм композиторлар музыкасын пропагандалау эшен дәвам итүче филармония муз.-әдәби лекторие (сәнгать җитәкчесе Л.А.Әхмәтова) эшләп килә. Т.ф. мәдәни-агарту эшчәнлеге алып бара, халыкара, бөтенроссия һәм төбәк дәрәҗәсендәге зур мәдәни чараларны тормышка ашыра. Әйдәп баручы солистлары — В.Васильев, Р.Галимова, Г.Ибушев һ.б.

Т.ф.нең директорлары — Л.А.Галиев (1937–38), А.Г.Садриев (1938–39), Б.Н.Абдуллин (1939–41), З.С.Әхмәтова (1941–44), Җ.Х.Фәйзи (1944–46), А.А.Юрусов (1947–48), Н.Г.Бадамшин (1951–52), М.Ф.Боголюбов (1952–61), Х.А.Калинина (1961–65), М.Г.Первин (1965–73), М.Г.Таҗетдинов (1973–88), Ә.З.Сафин (1989–2003), К.М.Нуруллин (2003 тән); сәнгать җитәкчеләре — А.М.Райский (1948 гә кадәр), Җ.Г.Садриҗиһанов (1948–49), А.С.Ключарёв (1950–52), Җ.Х.Фәйзи (1953–59), Р.К.Волкова (1959–64), А.З.Монасыйпов (1966), М.Н.Нигъмәтҗанов (1967–73), И.Г.Мәҗитов (1975–92), И.Г.Шакиров (1992–2003), А.Ф.Фәйзрахманов (2011 дән).

*Әд.:* Татарская государственная филармония имени Габдуллы Тукая. 1937–2007 гг. К., 2004.

**ТАТА́Р ХАЛКЫ́Н ГЫЙЛЬМИ́ ӨЙРӘНҮ́ ҖӘМГЫЯТЕ́.** 1923 елның 22 апрелендә Шәркыятьчеләр җәмгыяте җирлегендә оештырыла. Җитәкче органы — идарә. Җәмгыятьнең рәисе Н.Н.Фирсов, рәис урынбасары Г.Г.Ибраһимов (1928 гә кадәр). Идарә секретарьлары: М.Г.Худяков (1923–26), Е.И.Чернышёв (1925–26), Гали Рәхим (1926 дан). Җәмгыять әгъзалары: Н.Н.Воробьёв, Г.С.Гобәйдуллин, В.В.Егерев, М.Х.Корбангалиев, А.Г.Сәгъди, В.Ф.Смолин, М.Х.Таһиров, Җ.Вәлиди, Г.Ш.Шәрәф һ.б. (80 нән артык кеше). Җәмгыятьнең шәрәфле әгъзалары: академиклар В.В.Бартольд, М.И.Покровский, А.Н.Самойлович, профессорлар И.Н.Бороздин, В.А.Богородицкий һ.б. Башта ТАССР Мәгариф халык комис-тының *Гыйльми үзәге* составына керә, 1927 дән *Татар мәдәнияте йорты* каршында, 1929 дан *Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыятенең* мәдәният һәм көнкүреш секциясе буларак эшли. Татар халкы тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү б-н шөгыльләнә. Җәмгыятьнең программасы 1925 нең башында кабул ителә. Эшчәнлегенең төп юнәлешләре: тарих, этнография (татар халкы тарихы мәсьәләләрен өйрәнү, ТАССР терр-ясендә кульязма материаллар җыю, архив материалларын өйрәнү, археол. истәлекләрне өйрәнү һәм археол. карталар төзү); статистика һәм икътисад; әдәбият; сәнгать; табигать, *татар халкын өйрәнү гыйлеме* буенча библиография төзү. Җәмгыять эшчәнлегендә Идел буе халыкларының этнографиясе һәм төбәк археологиясе буенча тикшеренүләр уздыру мөһим урын били. Тарихи тикшеренүләр өлкәсендә эшләр шул чор «...яки күптән түгел узган заман» б-н бәйле мәсьәләләргә юнәлдерелә. Тикшеренүләрнең төп темалары — 17–19 йөзләрдә төбәктә аграр мәсьәлә, халык хәрәкәте һәм революцион хәрәкәт. Әлеге темалар тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгәнлектән, шул темалар буенча материаллар җыюга һәм бастыруга басым ясала. Җәмгыять үз эшчәнлегендә ТАССР терр-ясе б-н генә чикләнә, шунлыктан татар халкы тарихы һәм мәдәнияте буенча тулы һәм объектив карта төзү мөмкинлеге булмый. ТАССР Гыйльми үзәгенең финанс ярдәме б-н җәмгыятьнең басма органы — «Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте хәбәрчесе» (*«Вестник Научного общества татароведения»*, 1925–30, № 1–10) булдырыла. 1924 тән татар халкының көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, эпиграфик истәлекләрне өйрәнү һәм сирәк очрый торган материалларны җыю өчен даими рәвештә этнографик экспедицияләр оештырыла. Н.И.Воробьёв җитәкчелегендә — биш, П.М.Дульский һәм Гали Рәхим җитәкчелегендә ике комплекслы тарихи-төбәкне өйрәнү экспедицияләре уздырыла. Экспедицияләрдә Г.С.Гобәйдуллин, М.С.Гобәйдуллина, Ә.С.Гобәйдуллин, В.В.Егерев катнаша. Болгарда, Биләрдә, Иске Казанда, Казан Кремлендә археол. эзләү һәм казу эшләре алып барыла, Татарстанның археол. картасы төзелә. Язма истәлекләрне җыю һәм саклау буенча җәмгыять эшчәнлеге аеруча зур әһәмияткә ия була: археографик экспедицияләр үткәрелә, җәмгыять әгъзалары илдәге төрле архивларда эшлиләр. 1928 нең октябрендә Н.Н.Фирсов башлангычы б-н татар халкы тарихына караган материалларны эзләү һәм бастырып чыгару буенча археографик комиссия оештырыла. Җәмгыять СССРдагы 120 дән артык фәнни оешма, ш.у. чит ил галимнәре б-н хезмәттәшлек итә. Ул татар халкының социаль тарихы, мәдәнияте, көнкүреше, татар теле һәм әдәбияты мәсьәләләрен комплекслы тарихи-төбәкне өйрәнүгә сизелерлек өлеш кертә, Татарстанда нәшрият һәм музей эшләре, ш.у. төбәкне өйрәнү теориясе үсешенә булышлык итә. 1928 дән совет төбәкне өйрәнү гыйлемендә үзгәртеп кору башлана. Социалистик төзелешнең тизләтелгән алымнарына юнәлеш тоту төбәкне өйрәнү хәрәкәтендә дә чагыла. Төбәкне өйрәнү эшенең максаты буларак илдәге халык хуҗалыгы үсешенең 5 еллык планын тормышка ашыруга макс. ярдәм күрсәтү игълан ителә. Эзлекле рәвештә төбәкне өйрәнүче һәм фәнни оешмаларны ябу процессы гамәлгә ашырыла. 1928 нең мартында Татар мәдәнияте йорты президиумы РСФСР Баш фәнни идарәсенең Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте б-н Т.х.г.ө.җ.н бергә кушу тәкъдимен хуплый, җәмгыять Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте составына татар халкын өйрәнү секциясе (соңрак мәдәният һәм көнкүреш секциясе) сыйфатында керә, вакытлы басма чыгару хокукын саклый. Статус үзгәрү Т.х.г.ө.җ.нең гамәли эшчәнлегендә чагыла; ул секция буларак «практик» юнәлеш секцияләреннән соң икенче дәрәҗәдәге буынга әверелә.

*Әд.:* Синицына К.Р. Роль научных и краеведческих обществ в музейном строительстве в Татарии в 20-х — начале 30-х годов // Из истории Татарии: Сб. науч. тр. Госмузея Татарской АССР. К., 1996. Вып. 2; шул ук. Музейное строительство в Татарской АССР (1917–1967): Дис. ... К., 1970; Абдрашитова И.М. Вестник научного общества татароведения (1925–1930) // Уч. зап. Казан. гос. пед. ин-та. 1970. Вып. 80, сб. 4; шул ук. Из истории научного Общества татароведения (1923–1929 гг.): Вопросы историографии и ис-

точниковедения // Уч. зап. Казан. гос. пед. ин-та. 1975. Вып. 150, сб. 7; З а й ц е в А.В. Исторические учреждения Республики Татарстан в 20–30-е годы XX века. К., 1998.

*А.В.Зайцев.*

**ТАТА́Р ХАЛКЫ́Н ӨЙРӘНҮ́ ГЫЙЛЕМЕ́** (Татарика), татар халкының тарихын, телен, әдәбиятын өйрәнә торган фәнни дисциплиналарның җыелма атамасы. Татар халкын гыйльми өйрәнү 18 йөзнең 2 нче яртысыннан башлана, Петербург ФАнең *Академия экспедицияләре* барышында, 1768–74 елларда Идел буе, Себер, Урта Азия, Кавказ халыкларын планлы рәвештә этнолингвистик һәм тарихи-этногр. өйрәнүләргә керешелә. Т.х.ө.г. үсешенә Россия галим-натуралистлары П.С.*Паллас*, И.И.*Лепёхин*, И.И.*Георги* һ.б. шактый өлеш кертәләр. Татарларның борынгы истәлекләренә ш.у. 18 йөз — 19 йөз башы рус тарихчылары В.Н.*Татищев*, Н.М.*Карамзин* һ.б. мөрәҗәгать итәләр. Иң беренче Т.х.ө.г.н филол. фәне буларак үсә. Башлыча, татар телен һәм әдәбиятын өйрәнү, борынгы һәм урта гасырлар язма истәлекләрен, татар телендә әлифбалар, грамматикалар, хрестоматияләр һәм сүзлекләр бастырып чыгару б-н шөгыльләнә. 1778 дә Россиядә беренче дәреслек — С.*Хәлфин* китабы — «Татар теле әлифбасы», 1801 дә И.И.*Гигановның* «Татар теле грамматикасы», 1802 дә Н.*Атнометовның* «Татар вә гарәп әлифбасы» исемле китаплары басылып чыга. Казан ун-ты ачылганнан соң (1804) һәм анда 1807 дә Шәрекъ халыклары тарихын, мәдәниятен, тел үзенчәлекләрен өйрәнү үзәге — *Шәрекъ бүлеге* оештырылгач (Х.Д.Френ, И.Н.*Березин*, К.Ф.Фукс, Г.К.*Казимбәк*, И.*Хәлфин* һ.б.), Т.х.ө.г. өлкәсендәге эшләр активлаша. 18 йөз ахырында — 19 йөзнең икенче яртысында аның төп юнәлешләре: татар теленең, борынгы төрки һәм урта гасырлар язма истәлекләренең лексикасын һәм грамматик төзелешен өйрәнү; ш.у. татар грамматикаларын, хрестоматия һәм сүзлекләрен — И.Хәлфиннең «Татар теленең әлифбасы һәм грамматикасы...» (1809); А.А.*Троянскийның* «Татар теле грамматикасы...» (1814); А.К.Казимбәкнең «Төрек-татар телләре грамматикасы» (1839), «Төрек-татар телләренең гомуми грамматикасы» (1846); М.И.*Ивановның* «Татар грамматикасы», «Татар хрестоматиясе» (икесе дә — 1842 дә); Н.Н.*Булич*, И.Н.Березинның «Татар грамматикасы» (1857) хезмәтләрен һ.б.ны туплау һәм бастыру. Бер үк вакытта татар халкы тарихына бәйле тарихи-этногр. һәм әдәбият белеменнән беренче фәнни хезмәтләр: И.Хәлфиннең «Әхвале Чыңгызхан вә Аксак Тимер...» (1821), К.Ф.Фуксның «Казан татарлары статистик һәм этнографик нисбәттә» («Казанские татары в статистическом и этнографическом отношении», 1844) һ.б. басылып чыга. Китапханә, нумизматика кабинеты, Казан ун-тының сирәк әйберләр кабинеты татар халкы тарихына, мәдәниятенә һәм язмаларына кагылышлы археографик, нумизматик, археол., этногр. һ.б. материаллар б-н тулылана. Татар телендәге борынгы кульязмаларны барлау-өйрәнүгә Г.*Утыз Имәни*, татар халык иҗатын өйрәнүгә Г.Ваһапов, С.Кукляшев, Г.Фәезханов, Т.Яхин, К.*Насыйри* зур өлеш кертәләр. Татар сөйләм поэзиясенә ш.у. рус галимнәре И.Иванов, В.В.Радлов, Н.Ф.Катанов, С.Рыбаков, В.Мошков мөрәҗәгать итәләр, үзләренең хезмәтләрендә аеруча кызыклы үрнәкләрне теркиләр.

Казан ун-тыннан Шәрекъ бүлеге Петербург ун-тына күчерелгәннән соң (1855), татар халкын өйрәнүне 1878 дә Казанда оешкан *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* галимнәре (В.В.Радлов, И.Ф.Готвальд, Н.Ф.Катанов, К.Насыйри, Ш.Әхмәров, Һ.Атласи һ.б.) дәвам итә. «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре» басмасы бу өлкәдә зур вакыйга була. Анда татар халкының тарихы, археологиясе, этнографиясе һәм мәдәниятенә караган җитди хезмәтләр дөнья күрә. 19 йөзнең икенче яртысында — 20 йөз башында империя карамагындагы гыйльми учреждение һәм оешма вәкилләренең генә түгел, татар җәмгыятендәге зыялы шәхесләрнең дә татар халкы тарихын өйрәнү б-н кызыксынуы күзәтелә. Т.х.ө.г. ндә һәрдаим фәннәрнең аерылуы көчәя. Өстенлекле филол. мәсьәләләре б-н беррәттән тарихи, археол., этногр. һ.б. юнәлештә тикшеренүләр арта, филологиянең үзендә исә әдәбият белеменә караган өйрәнүләр аерымлана. Т.х.ө.г. комплекслы фән тармагыннан мөстәкыйль фән тармагына әверелә башлый.

Россиядә 19 йөз ахырында — 20 йөз башында чын мәгънәсендә Т.х.ө.г.нең милли формалашуы татар халкының иҗтимагый тормышында яңарыш идеологиясе — *җәдитчелек* таралуга, ш.у. халыкның милли үзаңы үсү һәм татар җәмгыятенең алдынгы Көнбатыш Европа мәдәнияте б-н кызыксынуы артуга бәйле. Әзлекле Т.х.ө.г.нә Ш.Мәрҗани нигез сала. Аның хезмәтләре татар тарихы, этнографиясе һәм тарихи-лингвистик чагыштырма тикшеренүләр үсешенең нигезе булып тора, шул сәбәпле татар халкының килеп чыгышы, татар әлифбасы барлыкка килү, татар-рус мөнәсәбәтләре тарихы мәсьәләләренә үзгә кызыксыну уята. Татар халкының килеп чыгышын һәм тарихын өйрәнүгә К.Насыйри, Р.Фәхретдин, Х.Габәши, Һ.Атласи, Г.Баттал, Ә.Вәлиди, Җ.Вәлиди, Г.Гобәйдуллин, К.Бикколов һ.б. күп көч куя. Бу процесста татар вакытлы матбугаты һәм милли нәшрият барлыкка килү уңай роль уйный. Ш.у. яңа татар әдәби теле барлыкка килү һәм дөньяви әдәбият формалашу уңай фактор булып тора. Галимнәр татар халкы мәдәнияте һәм тарихының фундаменталь һәм гамәли мәсьәләләрен, рухи традицияләрен, халык иҗатын һ.б. өйрәнүгә керешәләр. 1883–93 тә Г.Х.*Еникиев* тарафыннан 500 дән артык татар һәм башкорт җырлары туплана. Халык поэзиясе турында Г.Тукайның «Халык әдәбияты» (1910) әсәре үзенчәлекле теоретик хезмәт булып тора, ул 20 йөз татар фольклористикасында аерым урын били.

1920 дә ТАССР төзелгәннән соң татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыятьләре һәм оешмалары барлыкка килә, махсус татар халкын гыйльми өйрәнү вакытлы басмасы *«Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте хәбәрчесе»* ж-лы нәшер ителә башлый. 1921 дә Т.х.ө.г. өлкәсендәге эзләнүләрне максатчанрак төстә алып бару өчен *Гыйльми үзәк* оештырыла, аның составында *Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте, Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте, Татар мәдәнияте йорты* һ.б. эшли. Татар халкының тарихы һәм мәдәниятенә (М.Г.Худяков, Н.И.Воробьёв, С.Г.Вахиди, Г.С.Гобәйдуллин, Н.Н.Фирсов, Н.Ф.Калинин, Г.Рәхим һ.б.), иҗтимагый-сәяси эшчәнлеккә, милли азатлык көрәшенә (Г.Г.Ибраһимов, М.С.Сәгыйдуллин, Г.Г.Мансуров, Ф.К.Сәйфи-Казанлы һ.б.), татар әдәбиятына, фольклорына (Г.С.Гобәйдуллин, Г.Рәхим, Г.Г.Ибраһимов, Г.Г.Сәгъди, Г.Толымбай, Х.Бәдигый һ.б.) һәм тел белеменә (Җ.Вәлиди, Г.Х.Алпаров, В.А.Богородицкий, Г.Ш.Шәрәф һ.б.) караган төпле хезмәтләр языла. Ләкин татар халкы тарихын, килеп чыгышын өйрәнүне алга таба үстерү өчен Мәскәү, Ленинград, Казан һ.б. шәһәрләр архивларындагы татар халкы тарихына һәм мәдәниятенә караган яңа чыганакларны бастырып чыгарырга кирәк була. Татарлар күпләп яшәгән урыннарга оештырылган археографик һәм этногр. экспедицияләр дә зур әһәмияткә ия, экспедицияләр барышында татар халкының матди һәм рухи мәдәнияте турында сирәк мәгълүматлар, ш.у. берничә дистә мең борынгы төрки-татар китаплары һәм кульязмалары җыела. 1920 елларда татар алфавитын бердәм нормага китерү һәм гарәп графикасын латин графикасына алыштыру Т.х.ө.г. өлкәсендәге мөһим сәяси һәм фәнни мәсьәләләрнең берсе булып тора. 1926 да Бакуда 1 нче Бөтенсоюз тюркология конференциясе була, аның төп темасы — СССРдагы төрки халыкларның алфавитын үзгәртү; анда татар җәмәгатьчелеге вәкилләре дә (Г.Г.Ибраһимов, Г.Ш.Шәрәф, Г.С.Гобәйдуллин һ.б.) катнаша. 1920–30 елларда татар теле, аның орфографиясе өчен латин һәм рус алфавитларының фәнни нигезләре, ш.у. татар телен һәм әдәбиятын өйрәнү өчен дәреслекләр һәм укыту-методик әсбаплар эшләнә. «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре» («Известия Общества археологии, истории и этнографии»), «Татарстанны өйрәнү буенча материаллар» («Материалы по изучению Татарстана»), «Татарстанны өйрәнү җәмгыяте хезмәтләре» («Труды Общества изучения Татарстана»), «Татар мәдәнияте йорты хезмәтләре» («Труды Дома татарской культуры»), «Татарстан» ж-лы һ.б.да татар халкына караган дистәләгән фәнни хезмәт дөнья күрә.

1920 еллар ахырында — 1930 елларда, *индустрияләштерү, крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү* һәм *культура революциясе* кысаларында үтәлгән киң колачлы иҗтимагый-икътисади үзгәртеп корулар чорында Татарстанда татар халкы тарихын өйрәнү тәртипләре үзгәрә. Татар халкын һәм төбәкне гыйльми өйрәнүче ябылган учреждениеләр һәм җәмгыятьләр базасында төзелгән *Татарстан икътисад фәнни-тикшеренү институты* каршында татар халкын гыйльми өйрәнүне комплекслы оештыру мәсьәләсе тора. Әмма ул хәл ителми. 1937 гә күптомлы документлар һәм материаллар җыентыгының 1 нче томы гына («Татарстан тарихы доку-

ментларда һәм материалларда») басыла. Үзгәреш Икенче бөтендөнья сугышы башында, 1939 ның октябрендә, ТАССР ХКС каршында Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү ин-ты оештырылганнан соң Т.х.ө.г. өлкәсендә аерым мәсьәләләрне — татар теле, әдәбияты һәм фольклорына караган, ш.у. татар халкы һәм җирле төбәк тарихын өйрәнүгә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле шартлар булдырыла. 1941 нең февраленнән институт Татар теле, әдәбияты һәм тарих фәнни-тикшеренү ин-ты итеп үзгәртелә (1945 тән СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты). Татар халкы тарихына бәйле тикшеренүләрне оештыручылар: Н.А.Нигъмәтуллин, Х.Г.Шабанов, Х.Х.Ярмөхәммәтов, М.Х.Гайнуллин, Я.Х.Агишев, Л.Җ.Җәләй, А.Х.Хисмәтуллин, Г.С.Әмиров, Р.С.Газизов, А.Н.Григорьев, Е.И.Чернышёв һ.б. Әлеге өлкәдәге проблематиканы, башлыча, немец-фашист илбасарлары б-н көрәш шартлары билгели, шунлыктан игътибар үзәгендә төрки-татар героик эпосы (*«Идегәй»*) һ.б. тора. Әдәбият һәм фольклор белгечләре Г.Тукай һәм М.Гафури әсәрләрен басмага әзерләү өчен материал туплау б-н шөгыльләнәләр (Я.Х.Агишев, А.Х.Хисмәтуллин һ.б.). 1943 тә һәм 1948 дә Г.Тукай әсәрләреннән торган акад. басманың 2 томы чыга.

1950 еллардан Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты СССРда татар халкы тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүче эре үзәкләрнең берсенә әверелә. Институт оешканның беренче көннәреннән үк татар теле һәм әдәбияты мәсьәләләрен өйрәнү мөһим урын алып тора. Диалектология (Л.Г.Мәхмүтова, Д.Б.Рамазанова, Ф.С.Баязитова һ.б.), морфология (В.Н.Хангильдин, Ф.Ә.Ганиев һ.б.), синтаксис (В.Н.Хангильдин, М.З.Зәкиев һ.б.), лексикология (М.Г.Мөхәммәдиев, Ш.С.Ханбикова, Р.К.Рәхимова, Г.Х.Ахунҗанов, Ф.Ә.Ганиев, Р.Г.Әхмәтьянов һ.б.), болгар эпиграфикасы (Ф.С.Хәкимҗанов), гидронимнар (Ф.Г.Гарипова) һ.б. буенча зур күләмле эш башкарыла. 1977–81 дә 3 томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н чыгару (Р.Г.Әхмәтьянов, Г.Х.Ахунҗанов, С.Б.Вахитова, М.Г.Мөхәммәдиев, Ш.С.Ханбикова һ.б.) Т.х.ө.г. өлкәсендә гаять зур әһәмияткә ия.

1950–70 елларда татар әдәбияты өлкәсендә гомумиләштерүче хезмәтләр барлыкка килә: Г.Халит, Х.Хисмәтуллин һәм Ф.Гыйззәтуллин «XX йөз башында татар әдәбияты» монографиясен (1954) әзерлиләр, М.Х.Гайнуллинның — «XX йөз башында татар әдәбияты һәм публицистика» (1966), «XIX йөз татар әдәбияты» (1975), Г.Халитның — «Яңа чор (дәвер) поэзиясе» (1979) хезмәтләре, ш.у. күмәк басмалар: «Борынгы татар әдәбияты» (1963), «Татар совет әдәбияты тарихы» (1965) дөнья күрә. Әлеге чор әдәбият белеменә хас үзенчәлекләрнең берсе — татар әдәбияты тарихы буенча беренче дәреслекләр төзү. «Борынгы әдәбият тарихы» хезмәтендә (1963; төзүчеләре М.Х.Гайнуллин, Х.Мөхәммәтов, Х.Хисмәтуллин, Ш.Абилов һ.б.) татар әдәбияты үсеше тарихында яңа (болгар) концепция чагылыш таба. Дәреслек авторлары, татар халкының болгар этногенезына таянып, татар әдәбияты тарихын Идел буе Болгар дәүләте чорыннан башлыйлар. Хезмәттә беренче тапкыр шагыйрь Кол Гали иҗаты борынгы татар әдәбиятының аерылгысыз өлеше буларак анализлана. Татар язучылары Г.Тукай һәм М.Гафури (Г.Халит), Г.Камал һәм Ш.Камал (Х.Хисмәтуллин), Г.Коләхмәтов (Б.Гыйззәтуллин) һ.б.ның әсәрләренең әдәби үзенчәлекләрен анализлауга багышланган күмәк хезмәтләр бастырып чыгару да әдәбият белеме өлкәсендә зур әһәмияткә ия. Татар әдәбияты классикларының тормышы һәм иҗаты турында яңа мәгълүматлар М.Җәлилгә (1978), Г.Тукай (1979), Г.Ибраһимов (1980), Г.Камал (1981), М.Гафури (1981), Г.Коләхмәтов (1983), Һ.Такташ (1983) һ.б.га багышланган фәнни хезмәтләрнең тематик җыентыкларында бирелә. 6 томнан торган «Татар әдәбияты тарихы»н (1984–89) бастырып чыгару Т.х.ө.г. өлкәсендәге тикшеренүләргә керткән саллы өлеш була. Бу өлкәдә, аеруча 1970–80 елларда, татар фольклорын өйрәнүче белгечләр зур уңышларга ирешәләр. Фольклор әсәрләренең уникаль фондын туплау гаять мөһим була, шуның нигезендә 1976–88, 1993 тә 13 томнан торган «Татар халык иҗаты» фәнни җыентыгы басыла (төзүчеләре Х.Ш.Мәхмүтов, Ф.И.Урманчеев, И.Н.Надиров, Р.Ф.Ягъфәров, Х.Х.Ярмөхәммәтов).

Татар халкының этногенезы мәсьәләләрен хәл итү юлларын эзләүдә тарихчылар, этнографлар һәм археологлар зур өлеш кертәләр. Н.И.Воробьёв, Х.Г.Гыймади, Н.Ф.Калинин, А.П.Смирнов, А.Х.Халиковның татар халкы тарихын өйрәнүгә багышланган тикшеренүләре Т.х.ө.г.ндә татар этногенезы мәсьәләсен күтәрү өчен этәргеч булып тора. Төрки-татар цивилизацияләрнең башлангыч чорында үзенчәлекле булуын билгеләп, аларның килеп чыгышында иҗтимагый-икътисади сәбәпләрне аңлатып, галимнәр татар халкының барлыкка килүендә болгар теориясен дәлилиләр. Алтын Урда чорында этногенез мәсьәләсе татар халкы тарихында бәхәсле һәм аңлаешсыз моментларның берсе булып кала. Әлеге мәсьәлә СССР ФАнең *Фәнни сессиясендә* (1946) карала. Әлеге вакыйга татар халкының этник тарихын махсус өйрәнүнең бер этабы булып тора, сессиядә күп еллар дәвам иткән бәхәскә башлангыч йомгак ясала һәм алга таба татар халкы тарихын өйрәнүнең төп юнәлешләре билгеләнә. Тарихчылар, археологларның Идел буе Болгар дәүләтенә багышланган хезмәтләрендә, башлыча, аның тарихи әһәмияте, татар халкы формалашу тарихындагы урыны турындагы мәсьәләләр карала (Р.Г.Фәхретдинов, А.Х.Халиков). Казан ханлыгы тарихы анализлана, әмма тарихчыларның хезмәтләрендә 1980 еллар ахырына кадәр аның Рус дәүләтенә кушылуына уңай бәя турындагы фикер үстерелә, ул татар халкының этномәдәни алга баруына, камилләшүенә ярдәм итә дип аңлатыла (С.Х.Алишев). Татарстан АССР барлыкка килүдә Окт. рев-циясенең роле анализлана (М.К.Мөхәррәмов, И.Р.Таһиров, Р.К.Вәлиев). Татар буржуазиясе формалашу (Х.Х.Хәсәнов), татар крәстияннәренең иҗтимагый-икътисади үсеше (Ю.И.Смыков, И.А.Гыйләҗев), 1773–75 еллардагы Крәстияннәр сугышында татар халкы вәкилләре катнашу (С.Х.Алишев) мәсьәләләре өйрәнелә. Р.И.Нәфыйгов, И.Р.Таһиров, Р.К.Вәлиев, Р.Г.Хәйретдинов һ.б.ның хезмәтләре 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында Идел һәм Урал буендагы татарларның революцион-демократик хәрәкәтләренең үсеш тарихына, татар халкының милли-дәүләт төзелеше, татар китапчылыгы (Ә.Г.Кәримуллин), Бөек Ватан сугышы (Җ.И.Гыйльманов) тарихына багышлана. Татар этнографиясенең зур казанышы — «Урта Идел буе һәм Урал буе татарлары» («Татары Поволжья и Приуралья», 1967; төзүчеләре: Н.И.Воробьёв, Г.М.Хисаметдинов, Һ.В.Йосыпов, Р.Г.Мөхәммәтов, Х.Х.Ярмөхәммәтов һ.б.) исемле фундаменталь хезмәт басылып чыгу; археология казанышы — 6 томлык «Татарстан АССРның археологик картасы» хезмәте (1981–88; төзүчеләре: А.Х.Халиков, Һ.В.Йосыпов, Р.Г.Фәхретдинов, Р.С.Габәшев, Е.П.Казаков, П.Н.Старостин, Т.А.Хлебникова һ.б.).

1960–80 елларда Т.х.ө.г. мәсьәләләре Казан ун-ты галимнәре хезмәтләрендә аеруча мөһим урын алып тора. Татар әдәбият белеме (Х.Г.Госманов, И.З.Нуруллин, А.Г.Әхмәдуллин, Т.Н.Галиуллин, Р.К.Ганиева, Х.Й.Миңнегулов) һәм тел белеме (Д.Г.Тумашева, В.Х.Хаков, Г.Ф.Саттаров, Ф.М.Хисамова) мәсьәләләренә игътибар арта. Чыганакларны өйрәнүчеләрнең хезмәтләрендә татар халкының урта гасырлар тарихы мәсьәләләре шактый урын алып тора (Ш.Ф.Мөхәммәдьяров, И.П.Ермолаев, Р.Г.Кашафетдинов, М.Г.Госманов, А.С.Фәтхиев, Җ.С.Миңнуллин, Р.Ә.Шәйхиев, Д.Г.Мостафина). Алга таба татарлар яшәгән торак пунктларда археографик тикшеренүләр үткәрелә, алар барышында дистәләрчә мең иске татар китабы һәм кулъязмалары җыела.

СССР таркалу, Татарстанның суверенлашуы һәм татар халкының милли үзаңы үсү нәтиҗәсендә татар халкын өйрәнү юнәлеше тамырдан үзгәрә, милләт төзү тенденцияләренең әһәмияте арта бара. *Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе* оешу (1992) һәм аның карамагында татар халкы тарихын өйрәнүче яңа фәнни-тикшеренү оешмалары барлыкка килү (*Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, Тарих институты* һәм *Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*) татар халкының тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүне планлы һәм киң колачлы итә. 1990–2016 елларда Татар энциклопедиясе ин-ты (2015 тән — Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү ин-ты) коллективы тарафыннан рус һәм татар телләрендә «Татар энциклопедия сүзлеге», күптомлы «Татар энциклопедиясе»нең рус телендә барлык 6 нчы томы, татар телендә 1–5 нче томнары, Тарих ин-ты коллективы тарафыннан 7 томлык «Иң борынгы заманнардан алып татарлар тарихы» чыгарыла. Бер үк вакытта респ-кадагы акад. институтлар һәм югары уку йортларының әйдәп баручы галимнәре тарафыннан татар халкы тарихы төрле яклап өйрәнелә: татар халкы тарихы һәм милли төзе-

леш (С.Х.Алишев, И.Р.Таһиров, М.Г.Госманов, М.З.Зәкиев, Р.К.Вәлиев, Ф.А.Рәшитов, Р.Г.Әмирханов, Р.Г.Фәхретдинов, Д.М.Исхаков, А.Х.Мәхмүтова, Р.М.Мөхәммәтшин, И.Л.Измайлов, Р.Х.Теләшов, К.А.Әблязов, Ә.Г.Галләмова, А.Ю.Хәбетдинов), татар крәстияннәре һәм авыллары (И.А.Гыйләҗев, И.К.Заһидуллин, Р.В.Шәйдуллин); татар тарихи-мәдәни мирасы (Н.Х.Халитов, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, Р.М.Вәлиев, Р.Р.Хәйретдинов, Р.Р.Салихов, Р.А.Айнетдинов, Е.В.Липаков, Г.Р.Нәҗипова), татар археологиясе (А.Х.Халиков, Р.Г.Фәхретдинов, Е.П.Казаков, Ф.Ш.Хуҗин, Ә.Г.Мөхәммәдиев, Г.М.Дәүләтшин, А.Г.Ситдыйков), татар этнографиясе (Д.М.Исхаков, Н.А.Халиков, Р.К.Уразманова, Р.Н.Мусина, С.Ш.Сафина, С.В.Суслова), татар тел белеме һәм әдәбият белеме (М.З.Зәкиев, М.В.Гайнетдинов, Ф.Ә.Ганиев, Ф.М.Мусин, Ф.С.Хәкимҗанов, Ф.Ю.Юсупов, Л.К.Бәйрәмова, Ф.С.Сафиуллина, Д.Ф.Заһидуллина); татар милли иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләре һәм хәйрия җәмгыятьләренең барлыкка килүе һәм үсеше (Р.Р.Салихов, Л.М.Свердлова, Ф.М.Солтанов, Л.М.Айнетдинова, И.Р.Вәлиуллин, Җ.С.Миңнуллин, Р.Р.Фәхретдинов), Бөек Ватан сугышы (А.А.Иванов, И.А.Гыйләҗев, А.Ш.Кәбирова), татар энциклопедистикасы (Р.В.Шәйдуллин, Г.С.Сабирҗанов, А.Г.Яруллина, Л.М.Айнетдинова).

Татарстанда 20 йөзнең икенче яртысыннан башлап «Казан утлары», «Мәгърифәт», «Татарстан», «Мирас», «Чын мирас», «Безнең мирас», «Татарская археология», «Гасырлар авазы = Эхо веков», «Татарика», «Мәйдан», «Фәнни Татарстан» һ.б. исемдә гыйльми һәм әдәби журналлар басыла, аларда төп мәсьәләләр сыйфатында татар халкының тарихы, әдәбияты, тел белеме, мәдәнияте, мәгарифе яктыртыла.

Т.х.ө.г. чит илләрдә, нигездә, тарих-филол. өлкәсендә үсеш ала. Чит илләрдәге Т.х.ө.г. үзәге булып Төркия санала. Анда Төркия тарих җәмгыяте (1931 дә оештырыла), Төркия лингвистика җәмгыяте (1932 дә), Казан төркиләренең үзара ярдәмләшү һәм мәдәният җәмгыяте (1970 тә) эшли; 1970–80 елларда «Казан» ж-лы басыла. Төркиядә татар халкын өйрәнү 1920–30 елларда оешкан төстә формалаша. Т.х.ө.г. проблематикасының шактый өлеше 1920 елларда төрек милләтчелеген күкләргә күтәргән *пантюркизм* һәм *пантуранизм* идеологиясе б-н бәйле, бу татар эмигрантларының татар халкы тарихын өйрәнүләренә сизелерлек йогынты ясый (С.Н.Максуди, Й.Х.Акчура, Г.Баттал, Ә.Н.Курат, Ә.Вәлиди, Г.Исхакый һ.б.). 20 йөзнең икенче яртысында татар халкы тарихын өйрәнүне Н.Дәүләт, И.Төрекуглы дәвам иттерә. Т.х.ө.г. ш.у. Германиядә (Г. фон Менде, Б.Шпулер, А.Каппелер), АКШ (Б.Ижболдин, Ш.Юлай, А.-А.Рорлих, Ф.Брайн-Бенигсен), Венгрия (А.Вамбери), Франция (А.Беннигсен, Ш.Лемерсье-Келкеже, Ф.Жоржон, Я.Пеленский), Япониядә (Н.Ямаучи) һ.б. илләрдә үсеш ала. Чит илләрдәге университетларда һәм фәнни-тикшеренү үзәкләрендә татар теле өйрәнелә, төрле фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләр алып барыла. Ш.у.к. *Тюркология, Татарстан һәм татар халкы тарихын өйрәнү гыйлеме, Әдәбият белеме, Тел белеме.*

*Әд.:* Веселовский Н.И. Сведения об официальном преподавании восточных языков в России // Тр. Третьего Междунар. съезда ориенталистов в С.-Петербурге. СПб., 1876; Деятельность Общества татароведения (1923–1925) // Вестн. Науч. об-ва татароведения. 1925. № 1/2; Нуркай З. 5 лет научной работы // Вестн. Науч. об-ва татароведения. 1925. № 3; Абдрашитова И.М. Вестник Научного общества татароведения (1925–1930) // Уч. зап. Казан. пед. ин-та. 1970. Вып. 80, сб. 4; шул ук. Из истории Научного общества татароведения // Уч. зап. Казан. пед. ин-та. 1975. Вып. 150, сб. 7; Кононов А.Н. История изучения тюркских языков в России: Дооктябрьский период. Л., 1982; 50 лет поисков и открытий. К., 1989; Закиев М.З. Татары: проблемы истории и языка: Сб. статей. К., 1995; Зайцев А.В. Исторические учреждения Республики Татарстан в 20–30-е годы XX века. К., 1998; Татары. М., 2001; История татар с древнейших времён. В 7 томах. К., 2002–2014; Шайдуллин Р.В. Особенности становления и развития татароведения в России (вторая половина XVIII — первая треть XX вв.) // Наследие Мирзы Казем-Бека: история и современность: Доклады и сообщения международной научной конференции (Казань, 20–21 ноября 2013 г.). К., 2014; Поиски и открытия: роль научно-исследовательских институтов в становлении гуманитарного знания. К., 2015.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**ТАТА́Р ХАЛЫ́К АРХИТЕКТУ́РАСЫ**, татар халык осталарының, башлыча, агачтан архитектур-төзелеш иҗаты. Бура һәм каркас конструкцияле корылмалар болгар чорыннан ук билгеле. Т.х.а.ның сакланып калган истәлекләре 19 йөз ахыры — 20 йөз башына карый. Татар авылларында П-рәвешендәге утарларның берничә төре: ишегалларының ачык яки кышка ябыла торган алынма түбәләре, йорт б-н тоташкан яки хуҗалык корылмалары аерым урнашкан, бер яки ике ишегалды булган (каралтылы яки буш) төрләре төзелә. Рус утарларыннан аермалы буларак, йортлар утарның түрендә һәм хуҗалык каралтыларыннан аерым корыла. Татарларда алты почмаклы йорт аерым ишекле өйалдлары б-н берләштерелгән ике тигез бүлмәдән торган. Йортларның өч яклы төре аеруча үзенчәлекле була — мичкә ягыла торган ир-атлар һәм хатын-кызлар ягын зур өйалды берләштерә. Өйалдына исә келәт һәм хуҗалык бүлмәләре урнаша. Йортлар еш кына чарлак б-н төгәлләнә. Мондый йортлар, гадәттә, ике катлы булган. Аскы катның бер ягында келәт, икенчесендә аш бүлмәсе. Өске каттагы хуҗа бүлмәсенең тәрәзәләре урамга карый. Өйалды йортның ян диварлары ягына чыгып тора (планда әвернәсыман рәвештә), йортның композицияле һәм коммуникацияле үзәге булып әверелә. Келәтләрдән һәм баскычлардан башка, мондый йортларның икенче катында – гаиләнең өлкән әгъзалары, мезонинда кызлар өчен җылытулы бүлмәләр корыла. Хуҗалык каралтысы булган һәм буш ишегалдыннан өйалдына ике-өч ишек алып керә. Икенче кат һәм чарлак баскычлары уеп яки кырып ясалган текмәле рәшәткәләр б-н бизәлә. Мондый йортларда галанка мичләре чынаяк кирпечләр б-н тышлана. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында Казан артының бай сәүдәгәрләре бер-берсенә тәңгәл, өйалды аша асылмалы галерея — коридор б-н берләштерелгән традицион ике катлы ике өйдән торган комплекслы йортлар төзиләр. Йортлар такта б-н тышлана. Беренче катларда амбарлар, кибетләр, аш-су, хуҗалык бүлмәләре урнаша, беренче йортның югары катында хуҗа һәм аның өлкән уллары, икенчесенең шундый ук катында хатын-кызлар яши. Тәрәзәләфронтоннардагы керентеле куышларга кызлар бүлмәләре корыла. Алар ябыштырылган «нурлар бөҗрасы», декоратив колонналар һәм уеп ясалган рәшәткәләр б-н бизәлә. Тәрәзәләр уеп бизәгән йөзлекләр б-н каймалана. Өске рәшәткәләре уеп ясалган урам як коймалары, капкалары һәм баганалары уелган һәм ябыштырылган декор б-н чуарланган капкалары (кысалы яки кыек түбәле) татар утарлары бизәлешенең үзенчәлекле өлеше булып тора. Т.х.а.нда шәһәр архит-расы йогынтысында ордер элементлары да кулланыла. Утарларның капкалары һәм коймалары, йөзлек һәм фронтоннардагы ябыштырылган яки уеп ясалаган декор, фасад фрагментлары, ә кайвакыт бөтен өй берничә төскә буяп чыгыла. Бу аеруча Казан арты, Кама алды авылларына хас. Манарасы түбәгә урнаштырылган бер яки ике заллы агач мәчет традицион мәчетләр төренә керә. 19 йөзнең 2 нче яртысында халык осталары шәһәр архит-расы йогынтысында манаралары бинаның тонысыгына урнашкан мәчетләр төзи башлыйлар. Мәчет бинасы бүрәнә бурадан салына. Беркадәр борынгырак мәчетләрдә михраб, болдыр һәм манара бүрәнәдән корылган. 19 йөздә бүрәнә манаралар каркас конструкциягә алыштырыла — вертикаль баганалар такта б-н тышлана. Манара эчендәге бормалы баскыч мөәзинне азан әйтү мәйданчыгына (шәрәфәгә) алып менә. Шәрәфә әйләнәсе челтәрле балкон-галерея б-н әйләндереп алына, ул мәәзәнә дип атала. Манара биек чатыр б-н төгәлләнә. Мәчет һәм манара түбәләре яшел төскә, тышкы диварлар исә куе сары, күк, зәңгәр төсләргә буяла, кайвакыт ак юл б-н аралаштырыла. Пилястраларны, лопаткаларны, тәрәзә йөзлекләрен һ.б. детальләрне төрле төсләргә дә, ш.у. ак төс б-н аралаштырып та буйыйлар. Татар халык осталары мунча, амбар, ш.у. су һәм җил тегермәннәрен ике төрле: чатырлы һәм баганалы итеп төзиләр (Казан төбәгендәге башка халыкларда да киң тарала). Совет власте елларында утарларның һәм торак йортларның әүвәлгечә бизәлгән уртача төрләре саклана һәм үсеш ала.

*Әд.:* Ворбьёв Н.И. Материальная культура Казанских татар. К., 1953; Татары. М., 2001; Мухаметшин Ю.Г. Жилище татар Поволжья и Урала конца XIX — начала XX вв. К., 2007.

*Х.Г.Надыйрова.*

**«ТАТА́Р ХАЛЫ́К ИҖАТЫ́»**, татар фольклоры әсәрләре җыелмасы. 13 томлы фәнни басма, татар халык поэтик иҗатының барлык жанрларына караган әсәрләрне үз эченә ала. Басма 1976–93 елларда әзерләнеп нәшер ителә. Текст материалларының төп чыганагы булып ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының фольклор фонды һәм кульяз-




1




2



3



4



5

**Татар халык архитектурасы.** 1. 20 йөз башы татар авылы. Гомуми күренеше. График реконструкция; 2. Залесный посёлогындагы урам. Казанның Киров районы; 3. Залесный посёлогындагы торак йорт. Казанның Киров районы; 4. Базарлы Матак авылындагы «Шәүкәт» мәчете. Әлки районы. 1990 еллар; 5. Орнашбаш авылындагы чишмә өстендәге беседка. Арча районы.

малар мирасханәсе хезмәт итә. Татар халык эпосы, йола поэзиясе әсәрләре, тарихи жырлар һ.б. текстларның байтагы беренче тапкыр нәшер ителә.

**1 нче томга** (1976, төзүчесе И.Н.Надыйров) дүртьюллык җырлар — *кыска җырлар* кертелгән: хыял-өметләр, сагыну-сагыш, дуслык-туганлык, туган илгә, туган якка мәхәббәт, рекрутлар, солдатлар һәм хәрби әсирләр, шәкертләр, шахтёрлар һәм сукбайлар турында, табын, мәхәббәт җырлары, шаян җырлар һ.б. **2 нче том** (1977, төзүчесе Х.Ш.Мәхмүтов) *табышмакларны* эченә ала: күк җисемнәре, җир һәм су, табигать күренешләре, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы, кеше, туганлык һәм гаилә мөнәсәбәтләре, байлык һәм фәкыйрьлек, йорт һәм хуҗалык, һөнәрчелек турында, фәннәр, әдәбият, музыка, дин б-н бәйле һ.б. табышмаклар. **3 нче** (1977, төзүчеләре Х.Х.Гатина, Х.Х.Ярми), **4 нче** (1978, төзүчеләре Х.Х.Гатина, Х.Х.Ярми) һәм **5 нче** (1981, төзүчесе Л.Ш.Җамалетдинов) томнар *әкиятләрне* эченә ала: хайваннар турында, тылсымлы һәм көнкүреш әкиятләре. **6 нчы томга** (1979, төзүчеләре Х.Ш.Мәхмүтов, А.Х.Садыйкова) *мәзәкләр* кертелгән: социаль мәзәкләр (өстен сыйныфлар, байлар һәм ярлылар, мәхкәмә тикшерүләре, дин һәм дини йолалар, руханилар турында); кеше сыйфатлары турында (акыл һәм тапкырлык, хәйләкәрлек һәм ялкаулык, ахмаклык һәм наданлык, мактанчыклык һәм куркаклык, саранлык һәм комсызлык); кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре турында (мәхәббәт һәм дуслык, егетләр һәм кызлар, кияүләр һәм кәләшләр, ата-аналар һәм балалар), Хуҗа Насретдин турында һ.б. **7 нче томга** (1980, төзүчесе И.Н.Надыйров) *йола җырлары* (календарь һәм туй йолалары), *уен җырлары*, әйлән-бәйлән уены текстлары, *такмак* жанры әсәрләре, уен тасвирламалары һ.б. кергән. **8 нче томга** (1983, төзүчеләре Ф.В.Әхмәтова, И.Н.Надыйров, К.Б.Җамалетдинова) хәрби вакыйгалар һәм тарихи шәхесләр, хатын-кыз язмышы турында, сатирик һәм юмористик *бәетләр*; туган як, аналар һәм балалар, яшәү һәм үлем һ.б. турында *мөнәҗәтләр* кергән. **9 нчы том** (1984, төзүчесе Ф.В.Әхмәтова) *дастаннарны* үз эченә ала: тарихи, мәхәббәт, *Алыплар* турында. **10 нчы томга** (1987, төзүчесе Х.Ш.Мәхмүтов) җир һәм күк, табигать күренешләре, тән әгъзалары, хезмәт һәм ял, сату-алу, хуҗалык һәм көнкүреш әйберләре, гаилә һәм туганлык, яшәү һәм үлем һ.б. турында *мәкальләр, әйтемнәр, канатлы сүзләр*; яхшылык теләүләр һәм *каргышлар*, антлар, *сынамышлар* (һава торышы, булачак уңыш турында), ышанулар һ.б. кергән. **11 нче томга** (1987, төзүчесе С.М.Гыйләҗетдинов) *легендалар* һәм *риваятьләр* (тарихи: болгар чоры, Казан ханлыгының чәчәк ату һәм җимерелү чоры, татар мәгърифәтчеләре, Себер татарлары, авыллар тарихы турында; топонимик, көнкүреш), мифологик хикәяләр (*Өй иясе, Абзар иясе, Су анасы, Су бабасы, Су иясе, Шүрәле, Албасты, Убырлар* һ.б. турында) кергән. **12 нче томга** (1988, төзүчесе И.Н.Надыйров) *тарихи җырлар* (Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чорларындагы, рекрутлар һәм тоткыннар турында, революцион), лирик (туган ил, хатын-кыз язмышы, мәхәббәт, дуслык турында, шаян җырлар; совет чоры җырлары (туган ил, Ленин, Бөек Ватан сугышы һ.б. турында) кергән. **13 нче том** (1993, төзүчесе Р.Ф.Ягъфәров) балалар фольклоры әсәрләрен: багулар, бишек җырлары, такмазалар, шаярулар, санамышлар, үртәгечләр, тизәйткечләрне һ.б.ны үз эченә ала.

Һәр томның тәфсилле кереш мәкаләсе бар, анда жанрга характеристика бирелгән, жанрның үсеш тарихы, чорларга бүленеше, тематикасына күзәтү китерелә. Фольклор әсәрләренең күпчелегендә аларның беренче һәм аннан соңгы язмалары һәм басмалары, вариантлар саны, кайда һәм кем тарафыннан язып алынуы, кульязмаларның саклану урыны һ.б. турында мәгълүмат бирелә.

Җыентыкны төзүчеләр Х.Х.Ярми, И.Н.Надыйров, Х.Ш.Мәхмүтов, Ф.В.Әхмәтова һәм Л.Ш.Җамалетдинов ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә лаек булалар (1989).

1990 елларның 2 нче яртысында рус теленә тәрҗемәдә 14 томлы татар фольклоры җыентыгын нәшер итәргә керешелә; «Татар халык иҗаты»ның беренче 2 томы дөнья күрә (т. 1, 1999; т. 2, 2001). 2008 елдан башлап рус теленә тәрҗемәдә яңа 15 томлы татар фольклоры җыентыгын нәшер итү башлана (т. 1, 2008; т. 2, 2010; т. 3, 2010; т. 4, 2013). «Т.х.и.»ның 25 томлы киңәйтелгән һәм тулыландырылган яңа басмасын чыгару күздә тотыла.

*Әд.:* Татар халык иҗаты. К., 1951; Татар халык иҗаты: Кыска җырлар (дүртьюллыклар). К., 1976; Татар халык иҗаты: Балалар фольклоры. К., 1993.
*Ф.И.Урманчеев.*

**ТАТА́Р ХАЛЫ́К ЙОЛАЛАРЫ́**, тормыш-көнкүреш традицияләренә һәм дини йолаларга нигезләнгән тотрыклы гореф-гадәтләр. Т.х.й.на: *туй йолалары, бала туугa бәйле йолалар, мәет күмү һәм мәрхүмне искә алу йолалары,* ислам дине кабул ителгәнче булган *Тәңре* б-н бәйле ел фасылы (ел исәбенең хайваннар циклы һәм ай исемнәренең зодиак системасы б-н бәйле) йолалары керә. Т.х.й. мөселман йолалары б-н тыгыз бәйләнештә. Гаилә тормышына бәйле йолаларда татар халкы тарихындагы элеккеге иҗтимагый-хокук нормалары һәм искелекләр чагыла. Шуның б-н бергә билгеле бер урында тупланып яшәүче татар төркемнәренең һәрберсендә диярлек үзенчәлекле терминологияле үзгә йолалар комплексы барлыкка килә. Шулай булуга карамастан, әлеге йолаларның структура элементлары бер төрле. Бала тууга бәйле йолаларның бик күптәнгесе — «исем кушу», малайлар өчен ш.у. «*сөннәт*» (сөннәтләү). Туй йолаларын 3 төркемгә: туй алдыннан, туй вакытында һәм туйдан соң үткәрелә торган йолаларга бүләләр, аларда төп урынны димләү, ярәшү, килешү йолалары һәм *никах* алып тора. Татар-мөселманнарда мәет күмү һәм мәрхүмне искә алу йолалары ислам кануннары буенча, керәшен татарларда христиан динендәгечә (кайбер өстәмәләрне кертеп) башкарыла. Т.х.й. арасында мөселман бәйрәмнәре — *Корбан бәйрәме* һәм *Ураза бәйрәме* аерым урын алып тора, Корбан бәйрәме көннәрендә ирләр туганнары каберен зийарәт кылалар. Керәшен татарларда якыннары каберен зийарәт кылу «ата-аналар көннәре»ндә (христианнарда мәрхүмнәрне искә алу көннәре) башкарыла. Төп календарь Т.х.й. язгы-җәйге чорга туры килә (муллык һәм уңыш яз килү вакытына бәйле булганлыктан). Яңа ел бәйрәме «*Нәүруз*» язын көн б-н төн тигезләшкәндә бәйрәм ителә, чәчүгә кадәр *карга боткасы* йоласы үткәрелә, ул Казан татарларында *Сабан туе* бәйрәменә әзерләнү йоласының бер өлешен тәшкил итә (ш.у.к. *Сөрән*).

Т.х.й.нда чәчүне алдан юрауга зур әһәмият бирелә: мул уңыш алу өчен җиргә орлык б-н бергә йомырка салалар. Берaз чәчкәннән соң өстәл әзерләнә, анда пешкән йомырка б-н бер бөтен икмәк тә куела. Иген үскәндә һәм башак чыгарганда татар авылларында корбан («корбанлык», «шөкерана», «теләк») чалына. Мишәрләрдә — сарык, татарларның башка төркемнәрендә корбан итеп, гадәттә, сыер яки үгез чалалар, шуннан соң *намаз* укыла һәм табынга утыралар. Яңгыр теләү йоласы «яңгыр боткасы», «теләк боткасы», «киләмәт боткасы» — киләсе уңышны кайгырту б-н бәйле; йола буенча авыл халкы ботка ашаганнан соң бер-берсен су б-н коендыра. *Җыен* бәйрәменең аерым йолалары бар, ул язгы кыр эшләре тәмамлангач, ш.у. печәнгә һәм уракка төшкәнче үткәрелә. «Тәкәгә чыгу» (тәкә чалып) яки «тавыкка чыгу» (тавык суеп) — бер яки берничә гаиләнең табигатькә чыгу йоласы үзенчәлекле. «Хозурга чыгу» («сәхрә», «сахрага чыгу») — хатын-кызларның җыелышып табигать кочагында чәй эчү йоласы. Керәшеннәрдә «каен башын бәйләү» йоласы булган, ул Троицага туры китерелгән. Т.х.й. көз-кыш айларына азрак туры килә, алар арасында «*Нардуган*» бәйрәменә караганнары мөһимрәк санала. Моннан тыш, үзара кунакка йөрешү традицияләре яшәп килә, кагыйдә буларак, күрше рус авылында престол ярминкәләренә туры китерелә. Ярминкәдән соң «әртилле йөрү» башлана. Әлеге чорда Т.х.й.ннан *өмә* (татар халкында ярдәмләшү йоласы) аерым урын алып тора. «Каз өмәсе» (каз йолку), «тула өмәсе» (киез басу), «киндер тукмаклау» (киндер агарту) шундыйлардан. Совет чорында Т.х.й.на Яңа ел, 8 Март кебек дөньяви һәм коммунистик бәйрәмнәр килеп керде (бер үк вакытта дини йолалар һәм бәйрәмнәр тыела башлады). Совет чорыннан соң Т.х.й.ның күбесе тормышка кабат кайтарыла.

*Әд.:* К о б л о в Я.Д. О татарских мусульманских праздниках. К., 1907; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; У р а з м а н о в а Р.К. Современные обряды татарского народа. К., 1984; Татары. М., 2001.
*А.В.Климин.*

**ТАТА́Р ХАЛЫ́К СӘНГАТЕ́**, гамәли бизәлеш һәм сынлы сәнгать өлкәсе; сәнгать традицияләренең дәвамлылыгы нигезендә коллектив иҗат б-н барлыкка килгән әсәрләр. Синкретик характерга ия, матди һәм рухи мәдәният төре. Әйбер мохитен барлыкка китерә һәм рәсмиләштерә, халык тормышының көндәлек яшәү рәвеше һәм йола-тәртип кагыйдәләре б-н тыгыз бәйләнгән. Тарихи үсеш процессында этнотөбәк (Казан татарлары, татар-мишәрләр, Урал буе, Себер, Әстерхан һ.б. татарлар сәнгате) һәм конфессиональ (керәшен татарлар сәнгате) аерымлыклар барлыкка килә. 19 йөз башы — 20 йөз ахырында Т.х.с.нең гомуммилли формалары ныгып урнаша. Җитештерү характеры буенча аны өй хезмәте (әйберләрне шәхси ихтыяҗлар өчен әзерләү), һөнәрчелек хезмәте (заказга эшләү) һәм *халык нәфис кәсепчелеге* (кустарьчылык) төрләренә бүлеп йөртәләр. Элек барлык сәнгать халыкчан була; хезмәтнең иҗтимагый бүленеше һәм һөнәрчелек төрләре аерылып чыгу нәтиҗәсендә проф. сәнгать барлыкка килә. Татар халык сәнгатенең нәфислек системасы һәм орнамент теле борынгы төрки кабиләләр культурасына барып тоташа, һөнәрчелек иҗатының профессиональлеге урта гасырларда яшәгән төрки-татар дәүләтләре кысаларында барлыкка килә. Казан ханлыгы яулanganнан һәм татар шәһәр культурасы җимерелгәннән соң (16 йөз уртасы), крәстиян сәнгате һәм авылларга күчкән шәһәр һөнәрчелегенең үзара бәйләнеше Т.х.с.нең үсеш үзенчәлеген билгеле. Бу исә *зәргәрчелек сәнгате, укалап чигү, чигү, хаттатчылык,* ташка уеп эшләү (к. *Уеп ясалган кабер ташлары*), агачны уеп бизәкләү төрләренең югары сәнгать дәрәҗәсендә үсешенә сәбәп була. Зәргәрчелек бизәлешләрендә күпертмә җепкыр, хатын-кызлар калфаклары декорында *аппликация* сәнгатенең элмәкләп чигү техникасы, чигүле аяк киемнәре тегүдә — күн каю кебек тиңдәше булмаган башкару алымнары барлыкка килә. Башка техник алымнар (чүпләмле, сайлаулы һәм күпкөрле) б-н бергә үсеш алган күптөсле тукучылык эшләнмәләре, йола һәм көнкүреш әйберләрен бизәгәндә элмәләп, нагыш һәм элмәкләү ысулы б-н чигелгән чигешләр, татар халкының *милли киеме* үзенең купшылыгы һәм катлаулылыгы б-н аерылып тора. Татарлар яшәгән төбәкләрдә, башлыча, авыл җирендә киез басу (келәм-киезләр, киез аяк һәм баш киемнәре), *келәмчелек,* металл эшкәртү, чыпта сугу һәм камыш үрү, агачка һәм каен тузына уеп бизәк төшерү, челтәр бәйләү (к. *Челтәр бәйләү*), күнгә басма бизәк төшерү һәм аппликация һ.б. киң үсеш ала. Т.х.с.нең төп төрләре 18 йөздә — 20 йөз башларында авылларда һәм шәһәрләрдә һөнәрчеләр һәм осталарның вакытлыча читкә — башка татар авылларына, ш.у. башкорт һәм казакъ далаларына, Урта Азиягә акча эшләргә китүе формаларында үсеш ала. 19 йөз уртасыннан көнкүреш юнәлешендәге сәнгать продукциясе җитештерү күпчелек авыл халкының төп шөгыленә әйләнә һәм аның күп кенә төрләренә ярашкан авыл исемнәре барлыкка килә: Балтач — «балтачы», балта осталарыннан, Тимерче — тимерчеләрдән, Бакырчы — бакырчылардан, Чулпычы — чулпы ясаучы осталардан һ.б. 1840 еллардан Казанда һәм Казан артының якын-тирә авылларында (Арча, Дөбъяз, Әтнә һ.б.) каюлы күн аяк киемнәре һәм укалап чигелгән баш киемнәре (калфаклар, түбәтәйләр) җитештерү, читек, кәләпүш тегү һөнәрчелеге (к. *Каюлы күн*) барлыкка килә. Күп кенә Россия шәһәрләренең татар бистәләрендә кәсепчелек киң үсеш ала (Казан, Уфа, Әстерхан, Касыйм, Оренбург, Томск һ.б.). Капиталистик икътисад системасында эшләнмәләрне күпләп җитештерү татар халык сәнгатендә стереотип формаларның таралуына, төбәк һәм җирле аерымлыкларның юкка чыгуына, товар җитештерүче кустарьларны Т.х.с.дәге традицияләрдән аеруга китерә. 20 йөз башында арзанлы фабрика продукциясе б-н көндәшлекне күтәрә алмыйча, сәнгатьлелек ягыннан аеруча кыйммәтле төрләр һәм башкару техникасы: тукучылык техникасы, күпертмә җепкыр, элмәкле аппликация һ.б. юкка чыга башлый. Орнаментта натуралистик тенденцияләр (күбәләк, камка, күгәрчен рәсемнәре) барлыкка килә, затлы материаллар (алтын, көмеш) һәм катлаулы техник алымнарның (җепкыр, бөртекләү) имитацияләре тарала. 1920 дә товар кытлыгы шартларында оештырылган артельләр һәм кустарь остаханә кысаларында көнкүреш предметлары җитештерү дәвам итә. Моңа Бөтенроссия ҮБКның «Кустарьчылык сәнәгатенә булышлык итү чаралары турында»гы 1919 ел 26 апрель карары да ярдәм итә. 1920 елда элеккеге Казан губернасында 427 хезмәт артеле һәм ширкәт теркәлә. 1923 тә аларның күләме кинәт кими. Т.х.с.нең өйдә җитештерү б-н бәйле күп кенә төрләре (ташка уеп кисү, нәфис тукучылык, зәргәрчелек сәнгате, милли өс киемнәре тегү һ.б.) сүнә башлый, кайберләре (хаттатчылык һәм *шәмаилләр* язу) тыела. 1923–25 тә вак кәсепчелек-һөнәрчелек, ш.и. сәнгать сәнәгате тернәкләнеп китә. Чит ил-



**Татар халык сәнгате**. 1. Татар хатын-кызларының милли авыл киеме. 20 йөз башы; 2. Әтнә районы Олы Мәңгәр авылындагы торак йорт фронтоны фрагменты. Агач. Пычкы белән кисеп ясалган бизәк. 1960 еллар; 3. Идән keләме. Асалап туку техникасы. 1960 еллар. Әлмәт районының Нәдер авылы мәктәбе музее; 4. Йола сөлгесе. Чүпләмле туку техникасы. Яңа Чишмә районы Зирекле авылының Халык иҗаты һәм көнкүреше музее; 5. Беләзек. Көмеш акчалар. Уеплау. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы. ТР Милли музее; 6. Туй сөлгесе. Киндер, киҗе-мамык җеп. Тамбурлап чигү. 20 йөз уртасы. Яңа Чишмә районы Зирекле авылының Халык иҗаты һәм көнкүреше музее; 7. Бизәкле киез итекләр. Киез. 20 йөз башы. Кукмара районының Кукмара авылы; 8. Халык остасы М.Хәйруллина. Балтач районының Шеңшеңәр авылы. 1980 еллар.

ләрдә кәсепчелек эшләнмәләренә сорау арту сәбәпле, 1920–30 елларда читкә чыгару өчен бизәкле күн аяк киемнәре һәм зәргәрчелек әйберләре әзерләү саклана, халык иҗаты учакларына сүрелергә ирек куелмый. 1925 тә нәфис һөнәрчелек б-н шөгыльләнүче кәсепчеләрдән бизәкле аяк киемнәре һәм укалап чигелгән баш киемнәре тегүче — 1786, зәргәр (*Балык Бистәсе һөнәр-сәнгать остаханәсен* кертеп) — 203, комган ясаучы 32 кеше исәпкә алынган. Кәсепчеләр кооператив артельләренә берләшәләр; 1920 еллар уртасында Казанда кәсепчеләр һәм һөнәрчеләр җәмгыяте оештырыла (якынча 1 мең оста керә). 1920 дә Казан губерна земствосының Кәсепчелек музее базасында Кооперация һәм кәсепчелек сәнәгате музее ачыла (1927 гә кадәр эшли, директоры — Г.М.Залкинд), аның экспонатлары этнографик коллекцияләрдән, татар һәм рус гамәли-бизәлеш сәнгате әсәрләреннән тора. Экспортны киңәйтү һөнәри техник белем бирү үсешенә сәбәп була: Рязань губернасы Касыйм өязенең Татар волостена кергән Тәрби авылында «хатын-кызларның нәфис кул эшләрен» укыту-күрсәтмә остаханәсе, 1925 тә Бакчасарайда (Кырым) татар халык орнаменты мәктәбе ачыла. 1920 еллар ахырында Т.х.с.нә багышланган хезмәтләр барлыкка килә (П.*Дульский*, Н.*Воробьёв*, М.*Худяков*, Гали *Рәхим*, Б.*Адлер*, Е.Адольф һ.б.). Халык сәнгате әсәрләре беренче тапкыр Казандагы Татсовнархоз күргәзмәсендә (1921), Мәскәүдәге Бөтенсоюз а.х. һәм кустарь-сәнәгать күргәзмәләрендә (1923, 1927), чит илләрдәге гамәли сәнгать һәм бөтендөнья нәфис сәнәгать күргәзмәләрендә (Париж, 1925; Монце-Милано, 1927; Лейпциг, 1928 һ.б.) күрсәтелә. Мәскәүдәге Бөтенсоюз а.х. күргәзмәсендә даими үрнәк кустарь-сәнәгать экспозициясе өчен Казан арты халык архит-расы традицияләрендә (уеп бизәлгән йөзлекләр, төсле пыялалы тәрәзәләр, фронтон куышларындагы кечкенә балконнар, өч бүлемле бизәкле капкалар б-н) Татарстан Респ-касының ике катлы агач павильоны төзелә (1923). Анда этнография, халык сәнгате һәм татар мәгарифенә багышланган 3 экспозиция залы урнаша. 1925 тә күргәзмәгә Т.х.с.нә караган 117 әсәр тапшырыла (чигү, зәргәрчелек эшләнмәләре, укалап чигелгән баш киемнәре, бизәкләп тегелгән аяк киемнәре һ.б.). 1920 елларның 2 нче яртысыннан Т.х.с. өлкәсендәге эшчәнлек искелек калдыгы, шәхси инициатива күрсәтү дип игълан ителә. Артельләргә һәм һөнәр үзәкләренә кермәгән халык осталары кулаклар сыйныфына кертеләләр һәм сәнгать һөнәрләре б-н шөгыльләнүдән туктарга мәҗбүр булалар. Дәвамчанлык традициясе өзелә, 1930 еллар башыннан Т.х.с. бетүгә йөз тота. Кабатланмас әсәрләр һәм 1940 елларга кадәр сәнәгый юл б-н күпләп җитештерелгән кәсепчелек әйберләре арасында аерма зурая. Сугыштан соңгы елларда бары тик каюлы күн һөнәрчелегә генә тергезелә (соңрак Арчада милли аяк киемнәре ф-касы үзгәртеп корыла). 1960 еллар ахыры — 1970 еллар башында Т.х.с. традицияләре нигезендә эшләнмәләр чыгару буенча яңа пр-тиеләр: чигү һәм тукымага бизәк төшерү цехлары булган Казан нәфис эшләнмәләр ф-касы (1969), *Алексеев бизәкләп туку фабрикасы*, Саба р-ның Шәмәрдән посёлогындагы зәргәрчелек цехы (1969), Казанда сувенир ф-касы булган сәнгать заказларын өйдә эшләүче һөнәрчеләр комб-ты (1974) ачыла. 20 йөзнең 2 нче яртысында Т.х.с. авыл көнкүрешендә кирәк булган эшләнмәләр җитештерүче: паласлар һәм келәмнәр туку, чигү, тал чыбыгыннан йорт җиһазлары үрү, агачны уеп бизәү өйләр һәм торакны күп төсләргә буяу кебек аерым һөнәр төрләрендә саклана. Аерым осталар — ялгыз һөнәрчеләр хезмәтләрендә элмәләп чигү һәм сәйлән б-н бизәкләп чигү (М.*Бикбулатова*, Казан), йон келәмчелеге (Ә.Дәүләтшина, Алабуга ш.), көмеш каралту (Х.*Ганиев*, Саба р-ны Тенәки а.), җепкыр (Л.Хисамиева, Казан) һ.б.ш. эшләр очрый. Халык көнкүрешендәге күпчелек әйберләр вакытлар узу б-н гамәли кулланылышын югалта һәм хәзерге вакытта бары тик милли бизәлеш сәнгате үрнәге, сувенир әсәрләр сыйфатында гына эшләнә. Т.х.с. традицияләре Казандагы «Туран» милли-мәдәни үзәге фонды» ҖЧҖ (чигү, укалап чигү, каюлы күн, костюмнар), «Казан өйдә заказ алып эшләүче осталар комбинаты», «Традиция» фонды (укалап чигү), «Эбиволь» АҖ, Чаллыдагы «Карина» ҖЧҖ, Биектау р-ның Дөбъяз авылында каюлы күн әйберләр эшләп чыгаручы «Экоскин» ҖЧҖ; халык осталары һәм проф. рәссамнар әсәрләрендә (А.Артемьева, И.Васильева, И.*Гайнетдинов*, С.Гарбузова, Р.Гыймранова,

Ә.Җәмилова, С.Ислаева, Н.*Исмәгыйлев* (Нәкъкаш), Ф.Калмурзина, С.*Кузьминых*, Н.*Кумысникова*, Н.Мостафина, М.Салиева, Л.Фәсхетдинова, Р.Фәттахова, Ә.Шәмсетдинов) алар еш кына стильләшәләр һәм яңа кулланылышка ия булалар. Ш.у. «Актүбә уенчыгы», «Азнакай киез итеге» ҖЧҖ һ.б. барлыкка килә. 2003 тән халык осталары һәм үзешчәннәр — Һөнәрчеләр палатасына, проф. рәссамнар Рәссамнар берлегенең гамәли-бизәлеш сәнгать секциясенә берләшәләр. Ф.Х.*Вәлиев* 1970–80 елларда барлык эшчәнлеген Т.х.с. теориясен һәм сәнгатен өйрәнүгә, хәзерге заман мәдәниятендә аның традицияләрен яңартуга багышлый. Экспедицияләрдә аның тарафыннан тупланган материаллар ТР Дәүләт сынлы сәнгать музееның Т.х.с. тупланмалары нигезенә ята. Т.х.с. әсәрләренең зур тупланмалары ТР Милли музеенда, Татарстанның Яшел Үзән шәһәре, Яңа Чишмә р-ның Зирекле авылы һ.б. халык иҗаты һәм көнкүреше музейларында, Бөтенроссия гамәли-бизәлеш һәм халык сәнгате музеенда (Мәскәү), Россия этнография музеенда (С.-Петербург), Тубыл тарих-архит-ра музей-саклаулыгында, Касыйм шәһәре Тарих-туган якны өйрәнү музеенда, БР Милли музеенда (Уфа ш.) һәм Россиянең башка музейларында саклана лар. Ш.у.к. *Гамәли-бизәлеш сәнгате*.

*Әд.:* Д у л ь с к и й П.М. Искусство Казанских татар. М., 1925; ш у л у к. Народное искусство Татреспублики // Художественная культура Советского Востока. М.–Л., 1931; В о р о б ь ё в Н.И. Материальная культура Казанских татар. К., 1930; В а л е е в Ф.Х. Орнамент Казанских татар. К., 1969; ш у л у к. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ТАТА́Р ХАНЛЫКЛАРЫ́**, 15–16 йөзләрдә *Алтын Урда* таркалганнан соң барлыкка килгән дәүләтләр. *Ак Урда* җирлегендә *Олы Урда*, соңрак *Казан, Кырым* һәм *Әстерхан ханлыклары*; *Күк Урда* җирлегендә *Нугай Урдасы, Себер ханлыгы* һ.б. мөстәкыйль дәүләтләр оеша. Т.х.нда Алтын Урда чорыннан калган дәүләтчелек традицияләре — ханга буйсынган диван, төп идарәче ыруглар (*Аргын, Барын, Кыпчак, Ширин*), адм.-терр. бүленеш (олыслар, даругалар һ.б.), әмирләр, бәкләр, морзалар, угланнар, «кара халык» катлауларына бүленеш һ.б. саклана. Бу дәүләтләрдә бүгенге татар халкының төп төркемнәре (Әстерхан, Кырым, Казан, Себер татарлары һ.б.) формалаша. Ш.у.к. *Касыйм ханлыгы*.

*Әд.:* И с х а к о в Д.М. Тюрко-татарские государства XV–XVI вв. К., 2009.

**ТАТА́Р ЧАГЫЛДЫМЫ́** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 43 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зөя елгасы буенда. 2010 елда 46 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1721 гә кадәр нигез салына. 1920 елларга кадәрге рәсми чыганакларда, Чуаш Чагылдымы авылын да кертеп, Чагылдым исеме б-н бирелә. 1720 ләрдән халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–1860 елларда Удел ведомствосы карамагында; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Чагылдымда мөселман гыйбадәтханәсе, чиркәү-приход мәктәбе, 1 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 453,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Буа, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 154, 1897 дә — 327, 1913 тә — 366, 1920 дә — 437, 1926 да — 172, 1938 дә — 223, 1970 тә — 128, 1979 да — 96, 1989 да — 63, 2002 дә — 50 кеше.

**ТАТА́Р ЧАЛЛЫСЫ́** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 8 *км* көньяк-көнбатыштарак, Туйма елгасы буенда. 2010 елда 375 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә Саралы (хәзер Бехтерев) авылыннан күченүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рождественские Челны исеме б-н дә билгеле. Башта Алабуга Троица монастыре карамагында була. 1764 тә халкы экономик крәстияннәр катлавына күчерелә, 1780–1830 елларда Вотск тимер эшкәртү з-дына беркетелә, 1841 дә дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, йон-тукыма мануфактура б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, аракы з-ды, 2 су тегермәне, 2 базар (8 нояб. һәм 25 дек.), 20 йөз башында Троица чиркәве (1815–25 тә төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе (1868 дә нигез салына, 1889 га кадәр земство мәктәбе) эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3524 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Трёхсвятское волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1781 дә — 234, 1795 тә — 263 ир-ат; 1859 да — 922, 1887 дә — 1088, 1905 тә — 1226, 1920 дә — 2564, 1926 да — 1157, 1938 дә — 876, 1949 да — 621, 1958 дә — 531, 1970 тә — 491, 1979 да — 476, 1989 да — 425, 2002 дә — 399 кеше.

**ТАТА́Р ЧЕРКЕНЕ́** авылы, к. *Пучинкә-Енай*, Апас р-ны.

**ТАТА́Р ЧИЛЧӘСЕ́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 68 *км* көньяктарак, Чилчә елгасы буенда. 2010 елда 30 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп. 1926 да нигез салына. Түбән Чилчә исеме б-н дә билгеле. Оешкан көненнән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1926 да — 92, 1938 дә — 139, 1949 да — 137, 1958 дә — 111, 1970 тә — 122, 1989 да — 70, 2002 дә — 54 кеше.

**ТАТА́Р ЧИЯБАШЫ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 36 *км* көньяктарак, Шыя елгасы буенда. 2010 елда 242 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1690 елларда нигез салына; 1920 еллар уртасына кадәр (Рус Чиябашы авылын да кертеп) Чиябаш исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Рысова Поляна буларак та мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, Сергий Радонежский чиркәве, иске дин тарафдарлары гыйбадәтханәсе, земство мәктәбе, кредит ширкәте идарәсе, 13 тегермән, 14 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4293 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Юхмачы волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 188 ир-ат; 1859 да — 1379, 1897 дә — 2379, 1908 дә — 2783, 1920 дә — 1595, 1926 да — 754, 1938 дә — 564, 1949 да — 587, 1958 дә — 493, 1970 тә — 580, 1979 да — 549, 1989 да — 364, 2002 дә — 293 кеше.

**ТАТА́Р ЧУРАПАНЫ́** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 36 *км* көньяктарак, Зөя елгасыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 3 кеше (татарлар, чуашлар) яши. 1698 гә кадәр нигез салына. 1720 еллардан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–1860 та Удел ведомствосы карамагында; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Ч.нда мөселман гыйбадәтханәсе эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 120,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 442, 1897 дә — 93, 1913 тә — 46, 1920 дә — 123, 1926 да — 957, 1938 дә — 129, 1949 да — 125, 1958 — 97, 1970 тә — 44, 1979 да — 24, 1989 да — 10, 2002 дә — 3 кеше (1859, 1926 елгы мәгълүматлар Чуаш Чурапаны авылы халкын да кертеп бирелә).

**ТАТА́Р ШАТЫРШАНЫ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ульянов өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 308 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1653–54 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашманлык йөкләмәсен башкара; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Ш.нда 2 мәчет, мәдрәсә,

4 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 934,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Архангел волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 807, 1897 дә — 1030, 1913 тә — 1383, 1920 дә — 1383, 1926 да — 1541, 1989 да — 464, 2002 дә — 389 кеше.

**ТАТА́Р ШАТЫРШАНЫ́ ЦЕОЛИТЛА́Р ЧЫГАНАГЫ́**, Олы Яклы елгасының уңъяк ярында, субүләр киңлектә, Татар Шатыршаны авылыннан (Чүпрәле р-ны) төньяктарак урнашкан. 1990 елда А.Н.*Тюрин* тарафыннан ачыклана, 1991–94 тә эшкәртелә. Файдалы катламның яше соңгы акбур чорына карый, мергель-кремнийлы һәм цеолитлы токымнарның калынлыгы 20 дән 38 *м* га кадәр. Составында опокасыман, кремнезём-цеолитлы һәм известьташлы цеолитлы мергельләрдән торучы 4 катлам бар. Токымнарда цеолитлар (клиноптилотлар) һәм опал-кристобалитларның һәрберсенең күләме 15% тан ким түгел. Цеолитлы токымнар ачык соры, саргылт-сорыдан акка кадәр, нык түгел, зур күләмле һәм катламлы, борынгы белемнитларның (моллюскларның) «шайтан бармагы» дип йөртелә торган известьле кабырчык (ростр) ватыклары һәм пелеципода кабырчыклары эзләре сакланган. Т.Ш.ц.ч. токымнары адсорбент, ион алмаштыргыч сыйфатында эчәргә яраклы агымсуларны чистартуда, газ һәм һава киптерүдә, төзелеш материаллары һәм әйберләре компоненты буларак, игенчелектә — мелиорант һәм терлекчелектә, кошчылыкта өстәмә азык буларак кулланыла. Цеолитлы токымнарның запасы ($C_1$-$P_1$ категориясе буенча): терлекчелек ихтыяҗларына — 71, игенчелеккә — 36, төзелеш материаллары җитештерүгә — 56 млн. $м^3$.

*Әд.:* Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999; Агроминеральные ресурсы Татарстана и перспективы их использования. К., 2002.

**ТАТА́Р ШӘПКӘСЕ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 15 *км* көньяк-көнбатыштарак, Шәпкә елгасы буенда. 2010 елда 112 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 65%) яши. 1690 елларда нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Ш.ндә мәчет, мәдрәсә, 3 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1085 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Кузнечиха волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 128 ир-ат; 1859 да — 450, 1897 дә — 640, 1908 дә — 783, 1920 дә — 779, 1926 да — 364, 1938 дә — 204, 1949 да — 244, 1958 дә — 186, 1970 тә — 221, 1979 да — 178, 1989 да — 152, 2002 дә — 127 кеше.

**ТАТА́Р ШУГАНЫ́** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 43 *км* төньяктарак, Шуган елгасы буенда. 2010 елда 477 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысына кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Ушуган исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы асабалар, дәүләт крәстияннәре һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, ашлык саклау-сату кибете, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2134 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Кармалы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1816 да — 110 ир-ат; 1859 да — 286, 1870 тә — 787, 1897 дә — 927, 1906 да — 1061, 1926 да — 1545, 1938 дә — 1250, 1949 да — 980, 1958 дә — 897, 1970 тә — 949, 1979 да — 727, 1989 да — 578, 2002 дә — 529 кеше.

**ТАТА́Р ШУРАНЫ́** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 17 *км* төньяктарак, Ык елгасыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 137 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. 1735 кә кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Петровский, Катановка исемнәре б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 343 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Богодаровка волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1816 да — 110 ир-ат; 1859 да — 286, 1870 тә — 787, 1897 дә — 927, 1906 да — 1061, 1926 да — 1545, 1938 дә — 1250, 1949 да — 980, 1958 дә — 897, 1970 тә — 949, 1979 да — 727, 1989 да — 578, 2002 дә — 529 кеше.

**ТАТА́Р ЭНЦИКЛОПЕ́ДИЯСЕ ҺӘМ ТӨБӘКНЕ́ ӨЙРӘНҮ́ ИНСТИТУТЫ́**, ТР ФА-нең фәнни-тикшеренү һәм нәшрият учреждениесе. 1989 елда СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты составында Татар энциклопедиясе бүлеге буларак оештырыла (мөдире Ф.С.*Хәкимҗанов*), 1992 дә бүлек ТР ФА составына кертелә (мөдире Г.С.*Сабирҗанов*), 1994 тә Татар энциклопедиясе ин-ты итеп үзгәртелә. 2014 тән хәзерге исемдә. Эшчәнлегенең төп юнәлешләре рус һәм татар телләрендә күптомлы Татар энциклопедиясен, ш.у. тармак энциклопедияләре һәм башка фәнни басма-белешмәләкләр («Татарстан Республикасының торак пунктлары», «Казакъстан татарлары», «Татарстан Республикасының юкка чыккан авыллары», «Татарстан Республикасының табигате һәм табигый ресурслары», «Россия Федерациясендә татарлар тупланып яшәгән төбәкләр», «Татарстан археологиясе», «Чүпрәле районы» һ.б.) әзерләү һәм нәшер итү. 2016 да ин-т структурасы 4 фәнни-тикшеренү үзәгеннән гыйбарәт: энциклопедистика үзәге (мөдире Р.В.*Шәйдуллин*), татар диаспорасын өйрәнү үзәге (Б.Л.*Хәмидуллин*), Кама фәнни үзәге (Н.М.*Вәлиев*), төбәкне өйрәнү һәм иҗтимагый-мәдәни тикшеренүләр үзәге (Л.М.*Айнетдинова*). 2016 ел башына институтта 72 кеше, ш.и. 6 фән д-ры һәм 24 фән канд. эшли (10 хезмәткәр ТРның мактаулы исемнәренә лаек була). Рус һәм татар телләрендә Татар энциклопедиясе сүзлеген әзерләгән өчен В.Г.Абзалова, А.В.Гарзавина, Р.Н.Даутов, Р.М.Мөхәммәтшин, Г.С.Сабирҗанов, М.Х.Хәсәнов, Р.В.Шәйдуллинга ТРның Фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге бирелә (2005). Ин-тта 1 юнәлеш буенча аспирантура эшли (2012 елга кадәр 3 юнәлеш буенча). Ин-т Әзәрбайҗан, Белоруссия, Казакъстан, Молдова, Украина, ш.у. Башкортстан, Коми, Мари, Мордва, Удмурт, Чуаш Респ-калары, Мәскәү («Россия зур энциклопедиясе нәшрияты») һ.б. энциклопедик оешмалары (редакцияләре), ТР акад. оешмалары һәм югары уку йортлары, музейлары, иҗади берләшмәләре, ТР һәм РФ китапханәләре, төрле фәнни үзәкләр б-н элемтәдә тора.



Татар энциклопедиясе
һәм төбәкне өйрәнү институты.

Ин-тның төп басмалары: «Татарский энциклопедический словарь» (1999), «Татар энциклопедия сүзлеге» (2002), «Татарская энциклопедия (т. 1–6, 2002–14), «Татар энциклопедиясе» (1–5 т., 2008–16). «Татарстан Республикасы: табигать, икътисад, тарих, мәдәният, фән» («Республика Татарстан: природа, экономика, история, культура, наука», 2013, 2 нче басма 2015), «Татарстан: Иллюстрацияле энциклопедия» («Татарстан: Иллюстрированная энциклопедия», 2013; 2 нче басма 2015; 2014 тә Россия китап нәшриятлары берлегенең гран-приена һәм 1 нче дәрәҗәле дипломына лаек була), «Татарстан Республикасы: массакүләм мәгълүмат чаралары өчен энциклопедик белешмә» («Республика Татарстан: Энцикл. справ. для средств массовой информации», 2016), «Казакъстан татарлары» («Татары Казахстана», 2016), «Татарстан Республикасының юкка чыккан авыллары» («Исчезнувшие населённые пункты Республики Татарстан», 2016) һ.б. Ин-тның фәнни хезмәткәрләре «Габдулла Тукай: Энциклопедия» (2016); «Болгар шәһәре һәм Спас районы энцикло-

педиясе» («Энциклопедия города Болгар и Спасского района», 2015), «Сембер-Ульяновск төбәге татарлары: Энциклопедик белешмәлек» («Татары Симбирско-Ульяновского края: Энцикл. справ.», 2016) һ.б. хезмәтләрне әзерләүдә катнашалар.

Институт даими рәвештә үз фәнни җыентыкларын нәшер итә: «Россия һәм Татарстан тарихы: энциклопедик тикшеренүләрнең нәтиҗәләре һәм перспективалары» («История России и Татарстана: итоги и перспективы энциклопедических исследований»: Сб. статей итоговой науч. практ. конф.. К., 2009–16. Вып. 1–8); «Ватан һәм чит илләр тарихы, филологиясенең актуаль проблемалары (яшь галимнәр һәм аспирантлар карашы)» («Актуальные проблемы отечественной и зарубежной истории, филологии (взгляд молодых учёных и аспирантов)»: Сб. статей науч. практ. конф., К., 2012–16. Вып. 1–5).

Институт директорлары: М.Х.*Хәсәнов* (1994–2010), Р.М.*Вәлиев* (2010–15), И.А.*Гыйләҗев* (2015 тән).

**ТАТА́Р ЭСКАДРОНЫ́**, 1936 елда Польшада 13 нче Вильно улан полкының 1 нче эскадроны җирлегендә оештырыла. Командирлары: ротмистрлар М.Богданович, Б.Марцишович, Я.Тарновский, А.Ельяшевич, капелланы — Варшава гминасы имамы А.*Воронович*. Эскадронда, яңа гына хәрби хезмәткә алынган мөселманнардан тыш, христиан конфессиясе вәкилләре дә, ш.у. кече офицер полк мәктәбен тәмамлаган татарлар да (алар арасында — О.Байрашевский, Х.Смольский, И.Муравский, А.Байрашевский, М.Лебедь, С.Александрович, А.Гембицкий) хәрби хезмәт үтәләр. Т.э.на тулысынча мөселман кече офицерлары һәм уланнары взводы керә. Кавалеристлар мундирында аерым билге — йолдыз б-н ярымай була. Башка кавалерия частьлары арасында эскадрон махсус *бунчук* б-н аерылып тора. Татарларның ирекле ярдәменә таянып Т.э. мөселманнары өчен клуб төзелә. Эскадрон 1939 ның сентябрендә Икенче бөтендөнья сугышы башлану б-н Пиотрков шәһәре янында көрәшә башлый. Суховол торак пункты янындагы бәрелешләрдән соң эскадронның бер өлеше Венгриянең чигенә чигенергә мәҗбүр була, калган өлеше генерал Ф.Клеебергның «Полесье» оператив төркеме составына керә. 1939 ның 28 сентябрендә полк үзлегеннән тарала.

*Әд.:* Гришин Я.Я. Польско-литовские татары (наследники Золотой Орды). К., 1995.

*Я.Я.Гришин.*

**ТАТА́Р ЯЛТАНЫ́** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 34 *км* көньяктарак, Кече Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 485 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1700 еллар тирәсендә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Елтан, Служилая Елтань исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 3 мәчет (1830, 1875 һәм 1887 дә төзелә), мәдрәсә, 2 җил тегермәне, ярма яргыч, 10 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4150 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Изгар волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 145 ир-ат; 1859 да — 1375, 1897 дә — 1997, 1908 дә — 2100, 1920 дә — 2660, 1926 да — 2170, 1938 дә — 2069, 1949 да — 1312, 1958 дә — 1076, 1970 тә — 1071, 1979 да — 970, 1989 да — 648, 2002 дә — 579 кеше.

**ТАТА́Р ЯМАЛЫ́** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 20 *км* төньяк-көнбатыштарак, Агыйдел елгасы буенда. 2010 елда 400 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Я.да мәчет (1808 дән мәгълүм), бакалея кибете, ашлык саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2779,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Шәрип волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 137 ир-ат; 1859 да — 355, 1870 тә — 386, 1884 тә — 424, 1897 дә — 484, 1906 да — 556, 1913 тә — 575, 1920 дә — 593, 1926 да — 624, 1938 дә — 425, 1949 да — 577, 1958 дә — 381, 1970 һәм 1979 да — 516 шар, 1989 да — 435, 2002 дә — 408 кеше. Т.Я. янында *Татар Ямалы комплексы* урнашкан.

**ТАТА́Р ЯМАЛЫ́ КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Актаныш р-нының Татар Ямалы авылы янында урнашкан. Т.Я.к. истәлекләре 1954 елда Н.А.Мәҗитов, 1956–57 дә А.П.Шокуров, 1958 дә — В.Ф.Генинг, 1977–79 да Е.П.Казаков һ.б. тарафыннан өйрәнелә. Пьянобор археол. культурасына караган шәһәрлек һәм авыллыкны (бакыр кою остаханәсе табыла), Болгар археол. культурасына нисбәтле авыллыкны (12–14 йөзләр) үз эченә ала. Комплекс терр-ясендә мезолит чоры чакматаш эшләнмәләре, неолит чоры бизәкле керамикасы, бронза гасыр һәм *Пьянобор культурасы* учак урыннары, болгар керамикасы һәм Постпетрогром культурасына караган калку бизәкле савыт-саба тупланмалары табыла.

*Әд.:* Шокуров А.П. Материалы к археологической карте нижнего течения р.Белой и среднего течения р.Ик // Древности Башкирии. М., 1970; Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987; Археологические памятники Восточного Закамья. К., 1989.

*Е.П.Казаков.*

**ТАТА́Р ЯНТЫГЫ́** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 28 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Бырыс елгасы буенда. 2010 елда 366 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1710–11 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Я.нда 2 мәчет, мәдрәсә, 2 тегермән, ярма яргыч, 3 юлаучылар йорты, 9 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2484,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Чырпы волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1930 ның 10 августыннан — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Лаеш, 1944 нең 19 февраленнән — Солтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 122 ир-ат; 1859 да — 748, 1897 дә — 1232, 1908 дә — 1595, 1920 дә — 1675, 1926 да — 1541, 1938 дә — 1445, 1949 да — 1172, 1958 дә — 996, 1970 тә — 1007, 1979 да — 1329, 1989 да — 555, 2002 дә — 464 кеше.

**ТАТА́Р ЯРУСЫ́**, *Пермь системасының* (*чорының*) югары өлеше утырмалары; *Казан ярусыннан* соң килә. 265,8±1,0 млн. ел элек башлана, якынча 4,5 млн. ел дәвам итә. Триас системасы составында геолог С.Н.*Никитин* тарафыннан билгеләнә (1886), А.В.*Нечаев* 1915 елда Пермь системасына кертә. Т.я.ның 250 *м* га кадәр калынлыктагы утырмалары ТРның иң көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләрендә ачыкланган, кагыйдә буларак, алар субүләр пространство төзиләр. 3 горизонтка бүленә: Уржум, Северодвинск, Вятка. Нигездә, гипс катламлы күл-лагуналы чуар төстәге карбонатлы-балчыксыл токымнар һәм аллювиаль-дельталы кызыл төстәге комсу-балчыксыл токымнардан, мергель, известьташ, конгломерат линзалары, кремнийләшкән үзагач кисәкләреннән тора. Т.я. утырмаларында моллюск, остракодалар, балык, амфибия, җир өсте умырткалылары, эре рептилияләр (динозаврлар) һ.б.ның калдыклары очрый. Апас (Ишеево табылдыгы), Тәтеш (Монастырь чокыры) һәм Югары Ослан (Черёмушки ерымы) р-ннарында умырткалыларның сөякләре табыла. Т.я. токымнарында күп кенә төзелеш ташы (Яшел Үзән, Кукмара, Мамадыш һ.б. р-ннар), известьташ



Монастырь чокыры — Пермь системасы татар бүлегенең аскы чигендәге эталон геологик киселеш. Тәтеш районы.

(Апас, Балтач һ.б. р-ннар) һ.б. файдалы казылмаларның чагылмалары һәм чыганаклары ачыкланган. 2006 да Ведомствоара стратиграфик ком-т карары б-н Т.я. бүлек рангына күчерелә. Биармия бүлегенең Уржум ярусыннан соң килә. 260,4±0,4 млн. ел элек башлана, 9,0 млн. ел дәвам итә. Калынлыгы 100 *м* дан күбрәк. 2 яруска бүленә: Северодвинск (калынлыгы 90 *м* га кадәр) һәм Вятка (якынча 25 *м*).

*Әд.:* Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003; Стратиграфический кодекс России. СПб., 2006.

**ТАТА́Р-АМЕ́РИКА РЕГИОНА́ЛЬ ИНСТИТУТЫ́**, ТР Мәгариф министрлыгының югары уку йорты. 1993 елда көллият буларак ачыла, 1997 дән — ин-т. ТР бюджетыннан финансланучы ике югары уку йортының берсе (Татар гуманитар ин-ты б-н беррәттән). М.И.*Мәхмүтов* тарафыннан эшләнгән оригиналь концепциягә туры китереп, ин-тта АКШ югары уку йортлары б-н хезмәттәшлектә белгечләрне күп баскычлы әзерләү алып барыла. Укырга урта һәм тулы булмаган урта мәктәпне тәмамлаучылар кабул ителә, алар әзлекле рәвештә һөнәри, урта һөнәри һәм югары белем дипломнары ала. Югары белем бирү лингвистика һәм культурара коммуникация, тәрҗемә һәм тәрҗемә белеме, психология, дөнья икътисады, милли икътисад, менеджмент белгечлекләре буенча алып барыла. 2005 тә көндезге бүлектә — 720, читтән торып уку бүлегендә 380 студент укый. Якынча 5 мең белгеч әзерләнә. 2005 тән *Татар гуманитар-педагогика университеты* составына кертелә.

Җитәкчеләре: М.И.Мәхмүтов (1993–95), Д.М.*Шакирова* (1995–2005).

**ТАТА́Р-БАШКО́РТ АТЛЫ́ ПО́ЛКЛАРЫ**, 1812–14 елларда Россия армиясе составындагы хәрби частьлар. 1812 елда *Ватан сугышында*, 1813–14 тә рус армиясенең чит илләргә оештырылган сугыш хәрәкәтендә катнашалар. Хәрәкәттәге армиядә татар һәм башкорт атлыларыннан торган 30 дан артык полк (һәрберсендә 500 кеше) була. Сугыш башланганда генераллар П.И.Багратион, А.П.Тормасов, М.Б.Барклай-де-Толли армияләре составына керәләр. 1812 нең июнь–июль айларында Гродно, Вильно, Кобрин һ.б. шәһәрләр янында сугышалар. 1812 нең августында Бородино янындагы бәрелештә 1 нче типтәр полкы катнаша (соңыннан ул Калуга ополчениесенә һәм Д.Давыдовның партизан отряды составына керә). Т.-б.а.п. Мәскәүне Наполеон гаскәрләреннән азат итүдә катнашалар. Ул Россиядән чигенгәндә, генерал-лейтенантлар П.Х.Витгенштейн, П.К.Эссен, генерал Е.И.Чаплиц һ.б. җитәкчелек иткән гаскәрләр составында сугышалар; Украинада сугыш хәрәкәтләре алып баралар. Наполеон гаскәрләрен Көнбатыш Европа илләреннән сөрүдә катнашалар. 1813 тә Данциг шәһәрен штурмлыйлар, Берлин, Дрезден, Лейпциг һ.б. шәһәрләрне азат итүдә катнашалар. Рус армиясенең чит илләргә походы 1814 тә Парижга керү б-н тәмамлана. Сугыш еллары вакыйгалары татар бәетләрендә чагылыш таба («Без сугышка кергәндә / Бәхилләште барыбыз; / Без сугыштан чыкканда / Алдан чыктыданыбыз...»), анда француз гаскәрләре б-н аяусыз бәрелешләр турында сөйләнә. Француз генералы Марбо раславынча, сугышта татарлар һәм башкортлар, шөпшә күче кебек, шундук бөтен җирне сырып алалар, аларны куып җитү бик кыен була. Т.-б.а.п.ның күп кенә сугышчылары батырлык өчен бүләкләнә. 1812 елгы Ватан сугышын өйрәнүче Е.В.Тарле татар һәм башкорт сугышчыларына югары бәя бирә, алар «искиткеч нык һәм кыю» сугыштылар, дип яза.

*В.А.Шагалов.*

**ТАТА́Р-БАШКО́РТ АТЛЫЛАРЫ́**, к. *Татар-башкорт атлы полклары.*

**ТАТА́Р-БАШКО́РТ ЗАПА́С БАТАЛЬОНЫ́**, 1919 елның апрелендә Көнчыгыш фронтның 5 нче армиясе карамагында оештырыла. Командиры — А.Мадияров, командир ярдәмчесе — С.Әхмәтҗанов, хәрби комиссары — Х.Борнашев. Башта полкның барлык роталарыннан җыелган кызылармияче татарлардан һәм башкортлардан туплана. Өч ротадан һәм артиллерия инструкторлары командасыннан тора. Уфа, Казан, Самара, Сембер, Саратов, Вятка, Әстерхан, Пенза һ.б. губерналарның өяз хәрби комис-тларыннан мобилизацияләнгән кешеләр б-н; 5 нче армиянең татар-башкорт иреклеләре частьларын оештыру бүлекчәсе һәм Сембер шәһәренең 8 нче номерлы армия этабы коменданты идарәсе җибәргән ирекләләр һәм дошман ягыннан качып чыгучылар б-н; РВС каршындагы 5 нче армиянең махсус комиссиясе билгеләгән хәрби тоткыннар һәм качкыннар б-н тулыландырыла. Һәр ротада марш ротасы булдырыла. 1919 ның май–сентябрь айларында 5 нче армия сафларын тулыландырган 17 марш ротасы һәм аерым командалар составына 5000 нән артык кеше әзерләнә. Батальон Сызрань, Уфа, Чиләбе шәһәрләрендә урнаша. 1919 ның декабрендә Бәләбәй шәһәренә җибәрелә (15 командир, 189 кызылармияче), Идел буе татар укчыларының икенче аерым бригадасы составына керә.

*Әд.:* Гиззатуллин И.Г. Мусульманские военные организации (1917–1921 гг.). К., 2002.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**ТАТА́Р-БАШКО́РТ КОМАНДИРЛАРЫНЫ́Ң АЛТЫНЧЫ́ БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘ́Н МӘКТӘБЕ́**, милли хәрби уку йорты. 1923 елның ноябрендә *Казанда мөселман командирларының берләшкән курслары* нигезендә Кызыл Армиягә командирлар составы әзерләү өчен оештырыла. 1924 нең февралендә Татреспублика Советларының ҮБК исем. берләштерелгән татар-башкорт хәрби мәктәбе. Җитәкчеләре: И.И.*Тальковский*, С.А.Уласевич, М.П.Кирпонос; комиссарлары: Ш.Х.Усманов, С.С.Касыймов, К.Г.Нәҗми, Н.С.Еникиев, М.И.Обрываев. Татар, башкорт, казакъ һ.б. төрки халык вәкилләре курсантларын туплыйлар. Уку вакыты 3 ел тәшкил итә; гомуми фәннәр – татар телендә, белгечлек рус телендә укытыла. Мәктәп пехота, кавалерия, 1930 дан артиллерия өчен командирлар әзерли. 1935 тән – ТАССР ҮБК исем. татар-башкорт хәрби-пехота мәктәбе, 1936 дан ТАССР ҮБК исем. Казан укчылар мәктәбе дип үзгәртелә. Аннан соң шул база нигезендә пехота хәрби уч-щесе, соңрак танк уч-щесе дип үзгәртелә. 1924–36 да мәктәпне тәмамлаган 1258 кеше Кызыл Армия командирлары була.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**ТАТА́Р-БАШКО́РТ МӨСЕЛМА́Н СУЛ ЭСЕРЛА́Р ПА́РТИЯСЕ** (Идел-Урал татар-башкорт сул эсерлар партиясе). Казанда 1917 елның июль–августында оештырыла. «Ирек», «Аваз» г-талары редакцияләре каршындагы сул эсерлар төркемнәрен һәм мөселман социалистлар ком-тларының сул эсерлар фракцияләрен берләштерә. Җитәкчеләре — Г.Ибраһимов, Ш.Әхмәдиев һ.б. Казан һәм Уфа губерналарында Совет хакимиятен урнаштыруда катнаша. Сул эсерлар фетнәсе вакытында (1918) совет хакимиятен яклап чыга. 1919 ел башында партия таркала, күп кенә әгъзалары РКП(б) сафларына керә.

**ТАТА́Р-БАШКО́РТ СОВЕ́Т СОЦИАЛИ́СТИК РЕСПУ́БЛИКАСЫ** (ТБССР), РСФСР составында татар һәм башкорт милли дәүләтчелегенең фаразланган формасы; *Милләт Мәҗлесенең Идел-Урал Штатын* төзү карарына каршы юнәлтелгән дәүләт автономиясе төзү проекты (к. *Болак арты республикасы*). «Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасы турындагы фәрман»ны РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты, Үзәк мөселман комис-ты әзерли. Аңа 1918 елның 22 мартында И.Сталин, М.Вахитов, С.Диманштейн, Г.Ибраһимов, Ш.Манатов имза куялар. Ул 4 өлештән тора. 1 нче өлешендә Көньяк Урал һәм Урта Идел буе терр-яләре РСФСР составында Татар-Башкорт Респ-касы дип игълан ителә. 2 нче өлешендә респ-ка чикләрен билгеләгәндә «башкорт һәм татар революцион оешмалары» тарафыннан эшләнгән проект кулланыла дип күрсәтелә. ТБССР карамагына Уфа, Казан (өлешчә), Оренбург, Вятка, Пермь, Самара һәм Сембер губерналарының терр-яләре керергә тиеш була. 3 нче өлешендә, Башкорт респ-касы булуга карамастан, аның ТБССР б-н үзара мөнәсәбәтләре Оештыру съездында билгеләнергә тиешлеге ассызыклана. 4 нче өлешендә булачак җөмһүриятне оештыру съездын чакыру өчен Үзәк Мөселман комис-тына Махсус комиссия төзү йөкләнә (к. *Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасын гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча киңәшмәләр*). Советларның ТБССРны оештыру съездын ачу 1918 нең 13 сентябренә билгеләнә, ләкин ул булмый кала. РКП(б) ҮК Политбюросының 1919 ел 13 декабрь карары б-н ТБССР төзү турындагы фәрман гамәлдән чыгарыла.

*Әд.:* Хайрутдинов Р.Г. Трудное возрождение. К., 1992; Тагиров И.Р. История национальной государственности татарского народа и Татарстана. К., 2000.

**ТАТА́Р-БАШКО́РТ СОВЕ́Т СОЦИАЛИСТИ́К РЕСПУ́БЛИКАСЫН ГАМӘЛГӘ́ АШЫРУ́ МӘСЬӘЛӘСЕ́ БУЕНЧА́ КИҢӘШМӘЛӘ́Р**, Мәскәүдә узалар. 1 нчесе 1918 елның 13–15 апрелендә була, РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты-

ның Үзәк татар-башкорт комис-ты тарафыннан оештырыла. Киңәшмәләрне оештыру буенча комиссиягә Казан, Уфа һәм Оренбург Советларыннан, Казан мөселман, Уфа башкорт, Уфа татар, Оренбург башкорт комис-тларыннан, Уфа чуаш оешмасыннан берәр вәкил чакырырга дигән карар кабул ителә. Киңәшмә Казанда, М.М.Вахитов җитәкчелегендә ачыла; Президиумга М.Х.Солтангалиев (рәис), Н.А.Алексеев, Г.Е.Зиновьев кертелә. Киңәшмә эшендә ш.у. Идел-Урал Штатын гамәлгә ашыру һәйәте әгъзалары С.С.Атнагулов һәм Г.Ш.Шәрәф, Башкортстанның Вакытлы революцион Советыннан Ф.Ф.Солтанбәков катнаша. Татар-Башкорт ССР турындагы нигезләмә тикшерелә (к. *Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасы*). Г.Шәрәф татарларның һәм башкортларның уртак респ-касын булдыру проекты, булачак дәүләти берәмлекнең чикләре, төзелеше, халык саны турында тулы доклад ясый. Бәхәс барышында чикләр турындагы мәсьәлә иң мөһиме була; киңәшмәдә «Милләтләр эшләре буенча халык комис-тының Татар-Башкорт Респ-касы турындагы Нигезләмәсендә күрсәтелгән чикләрдә тукталырга, респ-каның тәмам тәгаенләнгән чикләрен респ-ка Советларының Оештыру съезды билгеләргә тиеш» дигән карар кабул ителә. Терр. яктан респ-ка чикләре эчендә яшәгән халыкларның мәнфәгатьләрен тулысынча исәпкә алу өчен Оештыру съездын чакыру комиссиясе составына чуаш, мари, мордва һәм удмурт халыклары вәкилләрен кертергә карар кылына. Ләкин киңәшмәдә съездны чакыру буенча комиссия оештырылмый. Кайбер губерналарның Советлары, ш.и. Казан губерна Советы, әлеге мәсьәләне хәл итүдә катнашудан читләшәләр. Киңәшмәдә оештырылачак респ-каны этнографик, геогр., геол., тарихи һәм мәдәни-сәнәгый яктан фәнни тикшерү өчен комиссия расланa.

2 нче киңәшмә 1918 нең 10–16 маенда Мәскәүдә уздырыла. Анда И.В.Сталин, М.М.Вахитов, К.Л.Якубов, Г.Г.Ибраһимов, К.Я.Грасис, Ф.Ф.Сыромолотов, Г.М.Енбаев һ.б. катнаша. Төп мәсьәләләр: Татар-Башкорт ССР Советларының Оештыру съездын чакыру буенча комиссия төзү, съездда катнашачак вәкиллекләрнең күләмен, съездны уздыру вакытын һәм урынын билгеләү һ.б. Респ-каны төзүгә каршылар (Сыромолотов, Грасис һ.б.) һәм аны яклаучылар (Вахитов, Ибраһимов, Якубов һ.б.) арасында бәхәсләр була. Оештыру съездын әзерләү комиссиясе раслана, аны уздыру урыны итеп Уфа шәһәре билгеләнә. 1919 ның 13 декабрендә РКП(б) ҮК Политбюросы карары б-н Татар-Башкорт ССРны төзү турындагы фәрманның юкка чыгарылуы сәбәпле, киңәшмәләрдә кабул ителгән чаралар гамәлгә ашмый кала.

Чыг.: Образование Татарской АССР: Сб. док. и материалов. К., 1963.

*Әд.:* Хайрутдинов Р.Г. Трудное возрождение. К., 1992.

**«ТАТА́Р-ИНФО́РМ»**, ТР мәгълүмат агентлыгы. 1993 елда ТР Президенты Указы б-н татарларның сәяси, социаль-икътисади һәм мәдәни тормышына кагылышлы мәгълүмат әзерләү һәм тарату өчен оештырыла. «Т.и.» КПССның Татарстан өлкә ком-ты бюросы карары б-н 1990 ның 6 июнендә оешкан хуҗалык исәбендәге мәгълүмат агентлыгы нигезендә барлыкка килә. Tatar-inform.ru сайтында Мәскәү, С.-Петербург, ТР шәһәрләре, Идел буе, Урал, Себер, Ерак Көнчыгыш, БДБ һәм Балтыйк буе илләрендәге агентлык хәбәрчеләренең 250 дән артык оператив мәгълүматы урнаштырыла, танылган сәясәтчеләр, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләренең комментарийлары китерелә, актуаль мәсьәләләр буенча Татарстанлыларның фикерләре чагылдырыла. Мәгълүмат татар, рус һәм инглиз телләрендә тарала. «Т.и.» 300 мең тираж б-н ТРның район һәм шәһәр газеталарында урнаштырыла торган 12 полосалы көндәлек кушымта чыгара. РФның иң эре 20 мәгълүмат агентлыгы исәбенә керә. 2008 дән төрки телле агентлыкларның халыкара ассоциациясе әгъзасы. Төрле еллардагы җитәкчеләре: У.Х.Богдалов (1993–98), Р.А.Ратникова (1998–2004), Р.З.Галләмов (2004–05), Л.Г.Толчинский (2005–16), Ш.М.Садыйков (2016 дан).

**ТАТА́РИЯ**, к. *Татарстан Республикасы.*

**ТАТА́РИЯ**, кече планета (№ 2668). 1976 елда Кырым астрофизика обсерваториясендә астроном Н.С.Черных тарафыннан ачыла. Исеме Татарстан Респ-касы хөрмәтенә бирелә. Кояштан ераклыгы 2,1 а.б.нән 2,5 а.б.нә кадәр үзгәрә. Кояш тирәли әйләнү периоды 3,5 ел.

**ТАТАРЛА́Р**, төрки телле халык, Татарстан Республикасының төп халкы (халык исәбен алулар буенча: 1989 елда — 1765 мең кеше, 2002 дә — 2019 мең кеше, 2010 да — 2012 мең кеше); РФдә сан буенча икенче урындагы төп халык (2002 дә — 5669,9 мең кеше, 2010 да — 5310 мең кеше).

**Т.ның атамасы тарихы һәм локаль үзатамалар.** Беренче тапкыр «Т.» атамасы 6–8 йөзләрдә «отуз-татар» һәм «токуз татар» рәвешендә Үзәк Азиядәге борынгы төрки кабиләләр арасында барлыкка килә (к. *Күлтәгингә куелган һәйкәлташ*). 10–12 йөзләрдә Үзәк Азиядә яшәгән татар дәүләти берләшмәләре 13 йөз башында Монгол империясенә кушыла. Аксөякләргә карата кулланылган «Т.» социаль яктан абруйлы атамага әверелә (Рәшидетдин). 13–15 йөзләрдә ул Җүчи Олысында (Алтын Урдада) үзенчәлекле империячел мәдәниятле хәрби-йомышлы катлау политонимы сыйфатында файдаланыла, 14 йөздән Т.ның зур өлеше мөселман динендә була. Алтын Урда таркалганнан соң аның терр-ясендә барлыкка килгән төрки-татар дәүләтләренең (*Әстерхан ханлыгы, Казан ханлыгы, Кырым ханлыгы, Себер ханлыгы, Касыйм ханлыгы* һ.б.) аксөякләре үзләрен элеккечә үк Т. дип атый. Урта гасырлар дәверендә «Т.» атамасы, экзоэтноним буларак, Русьта, Көнбатыш Европа һәм мөселман Шәрегы илләрендә Җүчи Олысының барлык халкына карата кулланыла. Идел-Урал төбәгендәге һәм Көнбатыш Себердәге татар ханлыкларын Рус дәүләтенә кушу (16 йөз — 17 йөз башы) нәтиҗәсендә аларның бердәм мәдәнияте терр. яктан бүлгәләнә, хәрби-йомышлы аксөякләрнең сыйнфый асылы бетерелә һәм халыкның бер өлеше христианлаштырыла, бу, ахыргы чиктә, «мөселман» конфессиональ атамасы б-н бергә, «Т.» атамасының халык массалары даирәсендә таралуына этәрә. 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында буржуаз үзгәртеп корулар һәм Россия империясендәге Т.ның милли иҗтимагый-сәяси хәрәкәте күтәрелеше барышында «Т.» атамасы нигезендә этник үзаңның яңа, милли тибы һәм аның б-н бәйле карашлар, мифологемалар формалаша. «Т.» төшенчәсе Идел-Урал төбәгендәге һәм Көнбатыш Себердәге күп кенә төрки этнотерр. төркемнәр өчен уртак атама үзлекләренә ия була. Акрынлап җирле, локаль (якташлык, этнокатлау һ.б.) үзатамалар: Идел буе — Урал алды Т.ының — мөселман, казанлы, мишәр (мещеряк), типтәр, керәшен, нагайбәк, качым һ.б., Әстерхан Т.ының — нугай, карагаш, юрт татарлары һ.б., Себер Т.ының — тубыллык, туралы, бараба, төмәнлек, бохарлык һ.б., Польша-Литва Т.ының мөслим, липка (литва) татарлары атамалары юкка чыга. 20 йөзнең 1 нче чирегендә «Т.» атамасы Идел-Урал төбәгендәге һәм Көнбатыш Себердәге төрки телле халыкның күпчелек өлеше өчен уртак атамага әверелә. 1926 елдагы халык исәбен алу мәгълүматлары буенча, Идел буендагы, Урал алдындагы (башкортлардан гайре) һәм Көнбатыш Себердәге төрки телле мөселманнарның зур өлеше «Т.» атамасын кабул итә.

**Т.ның таралып урнашуы.** Татар халкының төп үзәге — Идел буе–Урал алды Т.ы — Идел буе һәм Урал алды терр-ясендә формалаша. Т.ның даими һиҗрәте, бигрәк тә Идел буе–Урал алды Т.ының күчеше, Россиядә һәм дөньяда татар халкының тупланып һәм сибелеп яшәү урыннары күбәюгә китерә. Т.ның массачыл һиҗрәте татар ханлыклары Рус дәүләте тарафыннан яулանудан соң башлана һәм милли, социаль, дини изүнең кискен көчәюе б-н бәйле була. 18 йөздә Идел буеннан Урал алдына 220 меңгә якын кеше (Идел буе — Урал алды Т.ының өчтән бер өлеше чамасы) күчеп китә. 19 йөз ахырында Урал алдында, бигрәк тә Ык һәм Агыйдел елгалары арасындагы төбәктә, 1 млн.нан артык Т. яши. 19 йөзнең 2 нче яртысында, Россиядә капиталистик мөнәсәбәтләрнең бик тиз үсеше нәтиҗәсендә, Т.ның Идел-Урал төбәгеннән һиҗрәтенең төп агымы Россиянең Европа өлешендәге (Мәскәү тирәсе, Донбасс), Кавказдагы (Баку), Көнбатыш Себердәге сәнәгый яктан алга киткән р-ннарга юнәлә. 19 йөздә — 20 йөз башында Идел буе — Урал алды Т.ы сизелерлек дәрәҗәдә Әстерхан төбәгендәге һәм Көнбатыш Себердәге татар халкының этносостав өлешенә әвереләләр. 19 йөз башында алар Түбән Идел буендагы татар халкының 13,2% ын, 1830 да — 17,4% ын, 1900 дә — өчтән бер өлешеннән артыгын, 19 йөз ахырында Көнбатыш Себердәге барлык Т.ның 17 %ын тәшкил итәләр.

20 йөздә Т.ның таралып урнашуында җитди үзгәрешләр була. 1920–30 елларда аларның зур өлеше (1926 да — 95,4%, 1937 дә — 95,2%) РСФСРда яши. Бу вакытка аеруча эре татар диаспорасы Казакъстан һәм Урта


Азия терр-ясендә оеша (1926 да — 118,7 мең кеше, 1939 да — 129 мең кеше). Моннан тыш, Т.ның зур төркемнәре Украинада (Донбасс) һәм Әзәрбайҗанда (Баку) яши. 1959 елга РСФСРдан читтә, бигрәк тә Казакъстанда һәм Урта Азиядә Т.ның саны кискен арта (1959 да — 1944 тә ирексезләп сөрелгән Кырым Т.ын кертеп, 780 мең кеше). Бу төбәктә татар халкы исәбе үсешенә ш.у. Казакъстанның чирәм җирләрен үзләштерү дә йогынты ясый. 1989 га Урта Азия респ-каларында СССРдагы иң эре татар диаспорасы формалаша (1179,5 мең кеше). 1970–80 елларда Т.ның Көнбатыш Себергә һәм Ерак Көнчыгышка, аеруча нефть һәм газ чыгарылган р-ннарга, һиҗрәте көчәя (мәс., Төмән өлкәсендә татар халкының саны өч тапкыр арта).

2002 дәге халык исәбен алу мәгълүматлары буенча, Т. Идел-Урал төбәгендә (4614,3 меңгә якын кеше) һәм Көнбатыш Себердә (318,4 мең кеше) тупланып, РФнең барлык өлкәләрендә диярлек сибелеп (кушымтадагы 5 табл. к.) яшиләр. Т. ш.у. якын (Урта Азиядә һәм Казакъстанда — 644,5 мең кеше, Украинада — 73,3 мең, Әзәрбайҗанда — 28 мең, Белоруссиядә — 10,5 мең, Балтыйк буенда — 10,6 мең, Молдавиядә — 3,4 мең кеше) һәм ерак чит илләрдә (Румыниядә — 35 меңгә кадәр, Төркиядә — 20 меңгә якын, Кытайда — 5,6 мең, Польшада — 5,5 меңгә якын, Болгариядә — 5 мең, АКШта, Финляндиядә һәм ГФРда — 1 әр мең чамасы, Австралиядә — 0,5 мең, Канадада — 300, Венгриядә — 200, Даниядә — 150, Чехиядә — 150, Швециядә — 80 кеше, Японииядә — 30 гаилә һ.б.) яши. Ш.у.к. *Халык санын исәпкә алу*.

**Шәһәрләшү.** Хәзерге вакытта Т. — РФнең иң шәһәрләшкән халыкларының берсе. Т.ның шәһәрләшүе шәһәр торулыклары челтәре үсеш алган Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урда чорларында башлана. 16 йөзнең 2 нче яртысында — 17 йөз башында татар ханлыклары Рус дәүләтенә кушылганнан соң, Т. арасында шәһәр кешеләре катлавы кискен кими. 18–19 йөзләрдәге социаль-икътисади үзгәртеп корулар нәтиҗәсендә, бигрәк тә 1860 еллардан соң татар халкының шәһәрләшүе көчәя. 19 йөз ахырында Россия шәһәрләрендә яшәгән 240 мең татардан (барлык Т.ның 8,8% ы) 160 меңгә якыны (60% тан артыгы) Идел буе — Урал алды Т.ы була. 20 йөз башында Идел буе — Урал алды Т.ының шәһәрләшүе 5% тәшкил итә, аларның күпчелеге Идел буендагы һәм Урал алдындагы эре шәһәрләрдә (Казан, Уфа, Оренбург, Самара, Сембер, Саратов, Түбән Новгород, Кострома, Пенза, Екатеринбург, Пермь, Чиләбе, Троицк, Әстерхан һ.б.) яши. Көнбатыш Себердә шәһәрләшү акрын темплар б-н бара, 19 йөз ахырында шәһәр Т.ының 70% тан артык өлешен Идел буеннан һәм Урал алдыннан күченүчеләр тәшкил итә. Әстерхан Т.ының зур күпчелеге шәһәрләрдә яши. Польша-Литва Т.ында шәһәрләшү проценты аеруча зур була, 1830 елларда аларның 40% тан артык өлеше Минск, Новогрудок, Слоним, Гродно, Ковно (Каунас), Варшавада һ.б. шәһәрләрдә гомер кичерә. 1930–80 елларда, сәнәгатьнең һәм шәһәрләрнең үсешенә бәйле рәвештә, СССРда Т.ның яртысыннан күбрәге шәһәр халкына әверелә (1979 елда халык санын исәпкә алу мәгълүматлары буенча – барлык Т.ның 63% ы, 1989 елгы халык санын исәпкә алу мәгълүматлары буенча, 69% ы шәһәрләрдә яши).

**Төп этнотерриториаль төркемнәр:** Идел буе — Урал алды Т.лары, *Себер татарлары*, *Әстерхан татарлары*. Иң күпсанлы төркемнәрне — *Казан татарларын*, *Касыйм татарларын, мишәрләрне, керәшен татарлар* һәм *нагайбәкләр* субконфессиональ төркемнәрен үз эченә алган Идел буе — Урал алды Т.ы. Казан Т.ын, үз чиратында, этнографик төркемнәргә: үзәк, типтәр-башкорт (к. *Типтәрләр*), көньяк-көнчыгыш, пермь (к. *Пермь татарлары*), карин (чыпца; к. *Нократ татарлары*), ичкин төркемнәренә; Касыйм Т.ын — ак аймак, кара аймак, кара әрмәк, бастан (к. *Сасово татарлары*) төркемнәренә; мишәрләрне — төньяк, көньяк, ләмбрә, Урал алды төркемнәренә бүләләр. Себер Т.ы арасында Тубыл (тубыллык), Төмән (туралы), Бараба, Том буе (чат, эушта, колмак) Т.ы һәм этносословиеле бохари төркеме (бохарлык, сарт; *бохари төркиләр*) аерып күрсәтелә. Әстерхан Т.ын юрт, кундра Т.ына һәм нугай чыгышлы карагашларга бүләләр (элегрәк ш.у. «өч йорт» һәм «йомышчылар» төркемнәре дә була). Мөстәкыйль этник төркемне 14–17 йөзләрдә Алтын Урдадан һәм татар ханлыкларыннан Бөек Литва кенәзлегенә күчеп утырып, хәрби-йомышлы Т.ның этно-







**Татарлар.** Төп этнотерриториаль һәм этнографик төркемнәр: 1. Казан татарлары. 20 йөз башы; 2. Себер татар хатын-кызының традицион киеме; 3. Типтәр хатын-кызының традицион киеме; 4. Әстерхан татар хатын-кызы киеме. 19 йөзнең 2 нче яртысы; 5. Касыйм татар хатын-кызлары. 1925; 6. Түбән Новгород губернасы Сергач өязенең татар старшиналары. 20 йөз башы; 7. Керәшен татарлар. 19 йөз ахыры.

## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНДӘ ҺӘМ ЧИТ ИЛЛӘРДӘ ТАРАЛЫП УРНАШУЫ






РФ субъектларында һәм чит илләрдә яшәүче татарларның саны:

- 500000 нән артык
- 100 000 нән 500 000 гә кадәр
- 50000 нән 100000 гә кадәр
- 10000 нән 50000 гә кадәр
- 5000 нән 10000 гә кадәр
- 5000 нән ким

Картада саннар б-н билгеләнүче РФ субъектлары:

1 Ленинград өлкәсе
2 Новгород өлкәсе
3 Мордва Республикасы
4 Чуаш Республикасы
5 Мари Республикасы
6 Татарстан Республикасы
7 Удмурт Республикасы
8 Краснодар крае
9 Адыгея Республикасы
10 Ставрополь крае
11 Калмык Республикасы
12 Карачай-Чиркәс Республикасы
13 Кабарда-Балкар Республикасы
14 Төньяк Осетия Республикасы-Алания
15 Ингуш Республикасы
16 Чечен Республикасы
17 Дагъстан Республикасы
18 Еврей автономияле өлкәсе
19 Кырым Республикасы

Искәрмә: автономияле округлар кергән өлкәләрдән кала, үзәкләре б-н бер үк исемдәге өлкә атамалары картада күрсәтелми.

- Россия Федерациясе территориясе
- МИНСК — Дәүләт башкалалары
- Тула — РФ субъектлары үзәкләре
- Донецк — Шәһәрләр
- Дәүләт чикләре
- РФ субъектлары чикләре

Масштаб 1: 25 000 000

сословиеле берлеге буларак формалашкан *Польша-Литва татарлары* тәшкил итә. Гомуми килеп чыгышлары җирлегендә 13–15 йөзләрдә Т. б-н бәйле булган хәзерге кайбер халыклар һәм этник төркемнәр (*Кырым татарлары, нугайлар, башкортлар*, карачайлар, балкарлар, кумыклар һ.б.) тарихи үсеш процессында мөстәкыйль этнослар буларак формалашалар.

**Антропология.** Антропологик типология җәһәтендә Т.ны, нигездә, европеоид һәм монголоид расалары арасындагы Урал (Урал-лапоноид) төркеменә кертәләр (Г.Ф.Дебель, Н.Н.Чебоксаров, В.П.Алексеев). Т.да төрле антропологик элементларның булуы аларның этник яктан, башлыча, европеоид халыкның монголоид компонентлар б-н кушылуы җирлегендә формалашуын күрсәтә (к. *Антропология*).

**Сөйләм теле.** Т.ның күп гасырлар дәвамында формалашкан халык-сөйләм теле төрки телләрнең болгар-кыпчак төркеменә карый. Татар теле 3 диалектны: көнбатыш (*мишәр диалекты*), *урта диалектны* (Казан татарлары) һәм *көнчыгыш диалектны* (Себер татарлары) үз эченә ала. Диалектлар сөйләшләргә бүленә: көнбатыш диалектка — ц-лаштыручы (Сергач, Чүпрәле, Байкибаш) һәм ч-лаштыручы (Темников, Ләмберә, Кузнецк, Хвалын, Карсун, Мәләкәс, Волгоград, Куртин, Чистай керәшеннәре, Подберезье керәшеннәре, Эстәрлетамак, Шарлык һәм катнаш Чистай) сөйләшләр төркемнәре; урта диалектка — Балтач, Мамадыш, Лаеш, Бәрәңге, Нурлат, Кама Тамагы, Тархан, Минзәлә, Бөре, Златоуст, Төпекәй, Ичкин, ш.у. борынгылык сакланган Пермь, Нократ, Касыйм һәм керәшен татарлар сөйләшләре; көнчыгыш диалектка Тубыл-Иртыш сөйләшләре төркеме (Төмән, Тубыл, Тара, Саз арты, Тәбриз, ш.у. Бараба диалекты) һәм Том сөйләшләре төркеме (колмак һәм эушта-чат) керә. Әстерхан Т.ының теле көнбатыш һәм урта диалектларга якын, ләкин аның нугайлар теле һәм, ихтимал, Кырым Т.ы теле йогынтысы б-н бәйле үзенчәлекләре бар. Польша-Литва Т.ы, 16–17 йөзләрдә туган телләрен югалтып (ул тел Алтын Урда Т.ы теленә якын булган), белорус, өлешчә поляк һәм рус телләрен куллануга күчкәннәр. Т.ның хәзерге татар этносы б-н бергә формалашкан халык-сөйләм теле үзенчәлекләргә (лексика, фонетика, синтаксис һ.б.) ия, бу үзенчәлекләр Идел буе — Урал алды һәм Себер Т.ының дилектларын үзара берләштерә, аларны башка төрки телләрдән аерып тора. Татар теле күрше халыкларның телләре — төрки (нугай, чуаш, башкорт һ.б.), фин-угор (мордва, мари, удмурт һ.б.), славян (рус) телләре белән үзара актив багланышта булган. Т.ның формалашуы һәм үсеше чорында аларның теле Алтын Урдада Идел буе төрки теле (к. *Иске татар әдәби теле*) б-н бергә әлеге дәүләтнең ш.у. әдәби телләре булган гарәп һәм фарсы телләренең көчле йогынтысын кичерә (дин, фәлсәфә, мәгариф һәм мәдәният өлкәсендәге терминология). Хәзерге татар әдәби теле 19–20 йөзләр чигендә Казан Т.ының халык-сөйләм сөйләше нигезендә, мишәр диалектының сизелерлек катнашында формалаша. Ул билгеле бер дәрәҗәдә төрле халыкларның, ш.и. рус, нугай, чуаш, башкорт, мордва, мари һәм удмурт халыкларының этномәдәни йогынтысын кичерә.

**Язу.** Татар язма традицияләренең тамырлары нигезен Идел буе Болгар дәүләтендә кулланылган Орхон-Енисей язуы (к. *Орхон-Енисей язмалары*) тәшкил иткән 7–11 йөзләрдәге борынгы төрки рун ядкәрләренә барып тоташа. 922 елда ислам дине кабул ителү б-н болгарларның рәсми эш кәгазьләрендә *гарәп язуы* сизелерлек роль уйный башлый. Болгар әдәбиятының безнең көннәргәчә сакланган үрнәкләренең иң элгәргесе — Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы (1233). Алтын Урда дәверендә рәсми документларны төзегәндә башта уйгыр язуы, 14 йөз башыннан гарәп язуы кулланыла. Болгар теле һәм Алтын Урда халкының угыз-кыпчак тибындагы төрки теленең гомумшәһәр койнесы нигезендә яңа әдәби тел — Идел буе төрки теле формалаша, шул телдә иске татар әдәбияты үрнәкләре — Сәйф Сараиның «Китабе Гөлестан бит-төрки», Харәзминең «Мәхәббәтнамә», Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәрләре иҗат ителә. 20 йөзнең 1 нче утызъеллыгына кадәр Т. гарәп язуын кулланалар. 1928–29 да Т.ның гарәп язулы алфавиты — *латин язуы*, 1939–40 та руслаштырылган *кириллица* нигезендәге рус язуы б-н алыштырыла (к. *Алфавит*). 2000 дә ТРның Дәүләт Советы латин язуына күчү турында закон кабул итә, ләкин «РФ халыклары телләре турында»гы Федераль законга (2002) РФ терр-ясендә Россия халыклары телләрендә кириллица нигезендә булмаган алфавитларның кулланылуына юл куелмау турындагы төзәтмәләр кертелү аркасында аны гамәлгә ашыру туктатыла.

**Дин.** Дин тотучы Т.ның күпчелеге — хәнәфиләр мәзхәбендәге мөселман-сөнниләр (к. *Ислам*). Мөселман татарларның хәзерге дини үзәкләре — җитәкчеләре Россия мөфтиләр шурасына һәм *Россия һәм БДБның Европа илләре мөселманнары Үзәк Диния нәзарәтенә* берләшкән мөфтиятләрдән (Мәскәүдә, Казанда, Уфада, Саратовта, Әстерханда, Төмәндә һ.б. шәһәрләрдә) гыйбарәт. РФдә 2,6 меңләп мөселман татарлар мәхәлләсе исәпләнә. Россиядә ш.у. Т.ның бабалары 16–18 йөзләрдә христианлаштыруга дучар ителгән (к. *Православие миссионерлыгы*) аз санлы (2002 дә 35 меңләп кеше) субконфессиональ төркемнәре (керәшен Т., нагайбәкләр) яши.

**Килеп чыгышының төп концепцияләре.** Концепцияләрнең иң элгәресе — болгар-татар теориясе. Аның нигезендә Т.ның этник үзәген Урта Идел буенда һәм Урал алдында 8 йөздә (башка карашлар буенча, б.э.к. 8–7 йөзләрдә һәм элегрәк) оешкан болгар берлеге тәшкил иткән дигән фикер ята. Бу концепция буенча, хәзерге татар (болгар-татар) халкының төп этномәдәни традицияләре һәм этник үзенчәлекләре Идел буе Болгар дәүләтендә (10–13 йөзләр) формалашкан. Алтын Урда, татар ханлыклары, Россия дәүләте чорларында (16–19 йөзләр) алар бик аз үзгәрешләр кичергәннәр. Болгар бәклекләре (әмирлекләре), Алтын Урда составында булып, зур күләмдә сәяси һәм мәдәни автономиядән файдаланганнар. Урда хакимиятенең этносәяси системасы, ш.у. мәдәният (аерым алганда, әдәбият, сәнгать һәм архит-ра), болгар җәмгыятенә фәкать тышкы яктан гына йогынты ясап, моның тәэсире әллә ни сизелерлек булмаган. 13 йөздә монгол яулары нәтиҗәсендә Болгар дәүләте әмирлекләргә һәм солтанлыкларга таркалган, ш.у. бердәм болгар халкы 2 этнотерр. төркемгә (Мухша Олысы болгар-бортаслары һәм Идел-Чулман әмирлекләре болгарлары) бүленгән. Бу теория тарафдарлары Казан ханлыгы чорында болгар этносы монгол яуларына кадәр булган этносәяси үзенчәлекләрен ныгыткан һәм 1920 елларда татар буржуаз милләтчеләре һәм совет хакимияте «Т.» атамасын көчләп такканчыга кадәр этник яктан («болгар» үзатамасын кертеп) сакланган дип исәплиләр. Алар фикеренчә, Т.ның барлык башка төркемнәре (Себер, Әстерхан һәм Польша-Литва Т.ы) мөстәкыйль этник-мәдәни нигездә оешканнар, чынлыкта аерым этнослар булып, аларның Идел-Урал төбәгендәге болгарларның этник тарихына турыдан-туры катнашы юк. Концепция, нигездә, 19 йөз ахырында — 20 йөз башында эшләнә (Х.Габәши, Г.Әхмәров, Р.Фәхретдин һ.б. хезмәтләре). 1920 елларда, телнең стадияле үсеше һәм халыкларның автохтон килеп чыгышы теориясе (Маррның тел турындагы тәгълиматы) барлыкка килгәч, ул совет чоры галимнәре (Н.Н.Фирсов, М.Г.Худяков һ.б.) хезмәтләрендә алга таба үстерелә. 1920–30 елларда, совет тарих һәм лингвистика фәннәренә «ленинчыл-сталинчыл» идеология кертелү шартларында, ил историографиясендә болгар-татар концепциясе төп теориягә әверелә (А.П.Смирнов, Х.Г.Гыймади, Н.И.Воробьёв, Н.Ф.Калинин, Л.Җәләй һ.б. хезмәтләре). 1944 нең 9 августында ВКП(б) ҮКның «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында» карары кабул ителгәч һәм 1946 ның 25–26 апрелендә Казан Т.ының килеп чыгышы турындагы мәсьәлә буенча СССР ФА Фәнни сессиясе уздырылганнан соң, хакимиятләр тарафыннан рәсми хупланган әлеге концепция татар һәм совет историографиясендә беренчел рольне уйный башлый. Болгар чоры татар халкының килеп чыгышында иң мөһим этап буларак таныла, болгарларның һәм Т.ның мәдәни-эволюцион дәвамчылыгы турындагы фикер ныклап урнаша. 1980 еллар ахырына кадәр болгар-татар концепциясе тарихчылар, археологлар һәм тел галимнәре Һ.В.Йосыпов, А.Х.Халиков, М.З.Зәкиев, Ә.Г.Кәримуллин, С.Х.Вәлиев, Н.А.Томилов һ.б. тарафыннан актив үстерелә.

**Монгол-татар теориясе** Европага күчмә төрки-татар һәм монгол (Үзәк Азия) этник төркемнәренең күчеп килүе (бер гөман буенча — монгол яуларына кадәр, икенчесе буенча — Алтын Урда чорында), аларның, кыпчаклар белән кушылып һәм ислам дине кабул










Татарлар. Татар милли киеме (гравюралар): 1. «Казан татар хатын-кызы». 18 йөз. И.Георги хезмәтенә рәсемнәр альбомыннан; 2. «Казан татары». И.Георгиның «Россия дәүләтендә яшәүче барлык халыкларны тасвирлау» китабыннан буялган гравюра. 1799; 3. «Казан татарлары». К.Ф.Гун рәсеме буенча төсле литография. Кәгазь. 1862; 4. «Казан татар хатын-кызлары». Ф.Г.Солнцевның «Рус дәүләте киемнәре» китабыннан. Санкт-Петербург. 1869; 5. «Себер татар хатын-кызлары». Кошарев оригиналыннан К.Ф.Гун рәсеме буенча төсле литография. 1862; 6. «Томск татар хатын-кызы». Буялган гравюра. 19 йөз башы; 7. «Томск татары». Е.М.Корнеев рәсеме буенча О.Е.Скотников гравюрасы. 1809.

итеп, хәзерге татар мәдәниятенә нигез салуы турындагы фаразга таяна. Бу теория тарафдарлары, Идел Болгары өлешчә мөселманлашкан (ярым мәҗүси) халыклы, зәгыйфь үсешле дәүләт булган дигән фикердә торып, аның Казан Т.ы тарихындагы һәм мәдәниятендәге ролен инкарь итәләр яки киметәләр. Алар Алтын Урда чорында болгарларның зур өлеше килгән халык — югары шәһәр мәдәниятенә ия мөселманлашкан кыпчаклар тарафыннан этномәдәни йотылуга дучар ителгән, икенче бер өлеше (башлыча, мәҗүси болгарлар) Идел Болгарының чит төбәкләренә күченеп утырган һәм киләчәктә чуаш этносының (к. *Чуашлар*) нигезен хасил иткән дип исәплиләр. Шул ук вакытта кайбер авторлар Көнчыгыш Европа далалары һәм Идел аръягы, ш.и. Идел буе Болгар дәүләте халкының монгол яуларына кадәрге чорда ук «татарлаштырылуы» турындагы фикерне алга сөрәләр. Концепция 20 йөз башында Россия галимнәре (Н.И.Ашмарин, В.Ф.Смолин һ.б.) хезмәтләрендә барлыкка килә, аның кайбер аспектлары мөһаҗир татар галимнәре (Ә.Вәлиди, Р.Рәхмәти һ.б.) хезмәтләрендә алга таба үсеш ала. 1960 еллардан татар халкының монгол-татарлардан килеп чыгышы теориясен актив рәвештә чуаш (В.Ф.Каховский, В.Д.Дмитриев, Н.И.Егоров, М.Р.Федотов һ.б.), башкорт (Н.А.Мәҗитов һ.б.) һәм татар (Р.Г.Фәхретдинов, М.И.Әхмәтҗанов) үстерә башлыйлар.

**Төрки-татар теориясе**, Урал-Идел буе төбәгенә караганда татар милләте таралып урнашуының киңрәк этномәдәни ареалын күздә тота һәм яңа этнологик теориягә (конструктивизм, структурализм, яңа социаль тарих) нигезләнә. Аның тарафдарлары хәзерге Т.ның төрки-татар тамырларын ассызыклыйлар, аларның килеп чыгышында Идел Болгарының һәм Евразия далаларының кыпчак-кимәк этник төркемнәренең ролен күрсәтәләр. Татар этносының этник тарихында Алтын Урда чоры төп үсеш дәвере буларак карала, шул дәвердә монгол-татар һәм җирле болгар, кыпчак традицияләре нигезендә дәүләтчелек, мәдәният, әдәби тел алга таба үсеш кичерә, яңа тарихи традицияләр һәм «Т.» атамасы рәвешендә этносәяси үзаң оеша. Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән татар ханлыклары чорында аерым этнотерр. төркемнәр (Әстерхан, Казан, Кырым, Себер Т.ы һ.б.) формалаша. Бу чорда, бигрәк тә татар ханлыклары яулангannan соң, дини (мөселман) үзаң зур роль уйный башлый. 19 йөзнең 2 нче яртысында, татар җәмгыятенә буржуаз социаль-икътисади мөнәсәбәтләр актив үтеп керү, милли мәдәният күтәрелеше һәм татар этносының төрле терр. төркемнәре арасында мәдәни-интеграция бәгланышлары көчәю процессында татар этносының мәдәни-тарихи берлеге турындагы карашлар актуальләшә, татар идеологиясе рәвешендәге тарихи традиция яңадан булдырыла (Ш.Мәрҗани, И.Гаспринский, Һ.Атласи һ.б.), хәзерге Т. «этносәяси» милләте формалаша, гомуми «Т.» үзатамасы ныгып урнаша. 20 йөз башында бу теорияне Г.Гобәйдуллин үстерә; 1930 еллардагы репрессияләр барышында аның тарафдарлары юк ителә; бу юнәлешне күпмедер дәрәҗәдә язучы Н.Исәнбәт дәвам итәргә омтыла. 1940–90 елларда концепция чит илләрдәге татар галимнәре (Г.Баттал, Ә.Н.Курат, А.Рорлих, Н.Дәүләт, Ю.Шамилуглы) һәм татар халкын өйрәнүче чит ил галимнәре (А.Каппелер, А.Дж.Франк, М.Кемпер) хезмәтләрендә актив рәвештә эшләнә. СССРда 1960–80 елларда бу теориянең кайбер аспектлары татар тарихчылары М.Г.Сәфәргалиев, Ш.Ф.Мөхәммәдьяров, Х.Х.Хәсәнов, М.Г.Госманов, Р.Г.Әмирханов, этнолог Р.Г.Кузиев һәм филологлар Ә.Н.Нәҗип, Н.А.Баскаков, Ф.С.Фасиев тарафыннан үстерелә.

1990–2000 елларда концепция Ә.Г.Мөхәммәдиев, И.Р.Таһиров, Д.М.Исхаков, И.Л.Измайлов, Ф.Г.Рәшитов һ.б. хезмәтләрендә алга таба үсеш кичерә. Аның тарафдарлары Т.ның килеп чыгышын турыдан-туры Идел буе–Урал алды һәм Көнбатыш Себер төбәк-



Төркиләрнең авыр коралланган сугышчысы. 11–12 йөзләр.

ләренең төрки-татар (борынгы төрки-татарлар, болгарлар, хәзәрләр, кыпчаклар, кимәкләр, угызлар һ.б.) һәм фин-угор этник төркемнәре б-н бәйлиләр. Аларның күбесенең фикере буенча, хәзерге татар милләте формалашуга китергән этномәдәни процессларның нигезен тарихи-генетик һәм мәдәни-тел бердәмлеге (уртак мифологик бабалар, дини карашлар, тарихи язмыш һ.б.) рәвешендә халыкның үзаңында һәм «Т.» атамасында тупланулы чагылыш тапкан иҗтимагый-сәяси һәм дини-мәдәни факторлар тәшкил иткән.

**Дәүләтчелек традицияләренең** Т.да мең елдан арткан тарихы бар. Т.ның Көнчыгыш Төркестандагы һәм Монголиядәге этносәяси берләшмәләре турындагы тәүге хәбәрләр 6–8 йөзләргә карый. 7 йөздән башлап Көнчыгыш Европада бер-бер артлы төрки-болгар дәүләтләре (Бөек Болгар, Хәзәр каганлыгы, Идел буе Болгар дәүләте) барлыкка килә. 1208 дән Бөек Монгол дәүләте (Еке Монгол Улус) составында 1227–43 тә кыпчак, болгар, рус һ.б.ның дәүләтләрен һәм этносәяси берләшмәләрен үз эченә алган Җүчи Олысы үсеш ала. Җүчи Олысы дәүләт төзелешендә, башлыча, төрки-монгол традицияләрен дәвам итә, 13 йөзнең 2 нче яртысыннан үз язуы, шәһәр мәдәнияте, дәүләт төзелеше һәм бердәм этносәяси системасы (төрки-монгол кабиләләр системасы, идарәче аксөяк нәселләр, хәрби-йомышлы аксөякләр, корылтайлар), идарәче династиясе (Җүчиләр) һ.б. булган ислам төрки дәүләте рәвешенә керә башлый. Алтын Урда таркалганнан соң аның терр-ясендә шул дәүләтнең традицияләрен дәвам иткән яңа төрки-татар дәүләтләре — Казан, Төмән (Себер), Кырым, Әстерхан һәм Касыйм ханлыклары, Олы Урда, Нугай Урдасы һ.б. барлыкка килә. 16–18 йөзләрдә барлык татар ханлыклары Рус дәүләте тарафыннан яулана, ләкин иске дәүләт традицияләре халыкның бөтенлеген саклауда мөһим нигезләрнең берсе була.

20 йөз башында Т.ның үз дәүләтчелеген (баштa милли-мәдәни автономия рәвешендә) торгызу өчен көрәш көчәя. 1918 дә *Милләт Мәҗлесе Идел-Урал штатын* төзү турында карар кабул итә. 1918 нең 1 мартында аны гамәлгә ашыру омтылышы (к. «*Болак арты республикасы*») совет хөкүмәте тарафыннан өзелә. 1918 дә РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты *Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасы* турындагы нигезләмәне игълан итә (гамәлгә ашырылмый кала). 1920 дә РСФСР составында Татарстан АССР төзелә. Республика ЮСның 1990 ел 30 август декларациясе б-н ТАССР — ТССР, 1992 нең 7 февралендә ТР итеп үзгәртелә, 1992 нең март референдумыннан соң ТР РФ б-н ике респ-каның да конституцияләре, РФ һәм ТР арасында вәкаләтләр бүлешү турындагы шартнамәле мөнәсәбәтләр б-н бәйле суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты дип игълан ителә.


**Этносәяси тарих.** Хәзерге Т.ның бабалары, башка төрки халыкларның бабалары кебек үк, үзләренең килеп чыгышлары ягыннан Үзәк Азиянең (Алтай, Байкал аръягы, Монголия) төрле этносәяси берләшмәләргә кергән борынгы төрки халыклары б-н бәйле. 6 йөздә — 13 йөз башында Үзәк Азиядә борынгы татар этник төркемнәре кабилә берләшмәләре һәм дәүләтләр төзиләр. Монголия далаларында «утыз татар» этносәяси берлеге формалаша; 8 йөздә кытайларның һәм төркиләрнең хәрби-сәяси басымы нәтиҗәсендә ул берничә кабилә берләшмәсенә таркала. Алар арасында иң мәшһүре һәм көчлесе «тугыз татар» берләшмәсе була. Борынгы татар кабиләләренең (6–8 йөзләр) теле һәм мәдәнияте турында дөреслекне чагылдырган мәгълүматлар аз; кайбер тел белгечләре (француз шәркыятьче галиме П.Пеллио) аларны — төрки халык, башкалар (М.Ц.Мункуев, Ж.Желе) монголлар дип исәпли. Үзәк Азиядәге хәрби-сәяси вакыйгаларда «тугыз татар» кабиләләр берләшмәсе, еш кына кыргызларның аркадашлары булып, алар ягында Төрки каганлыкка каршы көрәшәләр (723–24 еллардагы сугыш). Ул каганлык таркалганнан соң, борынгы татар кабиләләре Көнчыгыш Төркестанда үзләренең угызлар б-н берлектә Уйгыр каганлыгына каршы сугыш алып барган этносәяси берләшмәләрен төзиләр. Уйгырлардан җиңелү нәтиҗәсендә аларның бер өлеше Уйгыр каганлыгы составына керә, аерым төркемнәре Көньяк Себергә күченеп, шунда кимәк-кыпчак кабиләләре б-н бергә Кимәк каганлыгы оештыралар. Гардизинең «Зәйн әл-әхбар» («Хәбәрләр бизәге», 11 йөз) әсәрендә әлеге каганлык идарәчесенең, кимәк традициясе буенча, Т. кабиләсеннән булуы турында әйтелә. 842 дә Уйгыр каганлыгы кыргызлар тарафыннан тар-мар ителә, борынгы татар кабиләләренең җирләре аларның биләмәләренә кушыла (бу хакта Тес елгасы үзәнендәге язуда күрсәтелә). 11 йөзнең 2 нче яртысында кыргызларны куганнан соң борынгы татар кабиләләре уйгыр бәкләкләре (Ганьчжоу, Турфан кенәзлекләре һ.б.) составына керәләр, соңрак Көнчыгыш Төркестан һәм Кытайның Ганьсу провинциясе чигендә үзләренең ярым бәйсез бәкләкләрен төзиләр. Көнчыгыш Төркестанда караханилар һәм тангутлар (Си Ся) дәүләтләре арасында көнбатыш борынгы татар кабиләләренең берничә бәклеге оештырыла. Алар Үзәк Азиядә актив тышкы сәясәт уздыралар (958, 996, 1039, 1084 тә Кытайга, 965, 981 дә Урта Азиягә илчеләр җибәрәләр һ.б.), Бөек ефәк юлын контрольгә алу өчен көрәшәләр, Ганьчжоу һәм Турфан бәкләкләре



«Татар җайдаклары». Бакырдагы гравюра. Рәссам Й.Я.Шейхцер. 1731.

б-н хәрби-сәяси берлекләр төзиләр. Әлеге татар бәкләкләренең идарәчеләре «апа-тәкин» («тәгин») титулын йөртәләр. 11–12 йөзләрдә борынгы татар этносәяси кабилә берләшмәләре Көньяк һәм Көнчыгыш Монголиядә, Төньяк Кытайда, Көнчыгыш Төркестанда зур терр-яләр билиләр. 13 йөз башында бу берләшмәләр *Монгол империясе* составында булалар (кытай чыганаклары мәгълүматлары буенча, борынгы татар кабиләләренең зур өлеше *Чыңгыз хан* тарафыннан кырыла, калган өлеше аның яуларында катнаша). Борынгы татар халыклары яшәгән бу терр-я Шәрекъ илләренең мөселман историографиясендә «Дәшти татар» («Татар даласы») исеме ала, «Т.» атамасы Үзәк Азия далалары халкының бер өлешенә берегеп кала. *Мәхмүд Кашгариның* 1072–74 тә төзегән «Диване лөгать әт-төрк» сүзлегендә Көнчыгыш Төркестандагы борынгы татар кабиләләренең теле төрки тел буларак теркәлгән. Фаразланганча, аларның төп өлеше будда динендә булган, башкалары манихейлык һәм ислам диннәрен тотканнар.

Идел-Урал төбәгендә Т.ның этник субстратын 7–9 йөзләрдә Үзәк Азия, Көньяк Себер һәм Төньяк Кавказдагы төрки дәүләтләр (*Төрки каганлык, Бөек Болгар дәүләте, Хәзәр каганлыгы, Кимәк каганлыгы*) халыклары б-н актив бәйләнештә яшәгән төрки һәм угор (венгрлар, *мажарлар* һ.б.) кабиләләре тәшкил иткән. Тыгыз этносара мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә Т.ның этник субстратына социаль җәһәттә үсеш алган болгар кабиләләре — болгарлар, барсиллар, бәрәнҗәрләр, савирлар һ.б. үтеп керә. 9 йөз ахырында — 10 йөз башында дәүләт төзү процессында болгарлар-




«Бай феодал йорты» (А.Х.Халиков реконструкциясе). 10–11 йөзләр. Биләр.

ның 910–70 елларда Урта Идел буенда Болгар һәм Суар бәклекләрен (әмирлекләрен) оештырган этносәяси берлекләре өстен чыга. Фаразланганча, 980 дә әлеге әмирлекләр һ.б. җирләр нигезендә *Идел буе Болгар дәүләте* төзелә. Болгар дәүләте нығу һәм аның терр-ясе киңәю барышында болгарлар актив рәвештә угыз-бәҗәнәк (*угызлар, бәҗәнәкләр*) һәм кыпчак (к. *Кыпчаклар*) кабиләләренең аерым төркемнәрен, ш.у. башка күрше этник төркемнәрне (*бортаслар, мажарлар* һ.б.) ассимиляцияләр (йоталар). 922 дә дәүләт дине сыйфатында ислам кабул ителү болгар этносы туплануда гаять зур әһәмияткә ия була. Бу норматив әдәби тел, этник историография (*Ягъкуб бине Ногманның* «Болгар тарихы» һ.б.) барлыкка килүгә һәм, ахыр чиктә, болгарларның гомуми мәдәнияте һәм этносәяси үзаңы формалашуга, тышкы мөселман дөньясы, барыннан да бигрәк Шәрекъ илләре б-н сәяси, икътисади һәм мәдәни бәйләнешләрнең киңәюенә этәргеч бирә. 10–13 йөзләрдә Евразия далаларында борынгы Т.ның, кыпчак-кимәкләрнең, болгарларның һ.б. төркиләрнең дәүләти берләшмәләре оеша. Алар эчендә төрки кабиләләрнең туплану процессы бара, мөселман фикере йогынтысы көчәя.

1220–40 елларда Төньяк Евразиянең күп кенә дәүләтләре һәм кабиләләре монгол ханнары тарафыннан яулана һәм Җүчи Олысы составына керә. Утрак дәүләтләр (рус кенәзлекләре, әмирлекләргә таркалган Идел Болгары, Харәзем) вассал биләмәләргә әверелә, ш.и. Идел буе Болгар дәүләтенең элеккеге терр-ясе хан биләмәсенең бер өлеше була, кимәк-кыпчакларның кабилә берлекләре таркала, аларның аксөякләренең бер өлеше кырып бетерелә, икенче өлеше Җүчи аксөякләре составына кушыла, Дәште Кыпчак (Евразия далалары) халкы Җүчи Олысының хәрби-адм. һәм клан системасына кертелә. 13 йөз уртасында кабиләләрнең монгол яуларына кадәрге исемнәре югала баруы һәм аларның урта гасырлар Т.ының терр. төркемнәренә карата төрле җыелмада кулланылган төрки-монгол атамаларына (кыят, найман, коңграт, кереит, катай, мангыт, бөркүт, җалаир, уйшут һ.б.) алмаштырыла башлавы, 4 идарәче ыруг (Ширин, Барын, Аргын, Кыпчак) барлыкка килүе хас. Әлеге татар (төрки-монгол) нәселләренең йогынтысы Түбән Идел буенда, Урал алдында һәм Көнбатыш Себердә аеруча көчле була, алар шул төбәкләрдәге угор һәм кыпчак-кимәк ыругларын үз структураларына кертәләр һәм, башлыча, ассимиляцияләр. Нәкъ менә шул чордан Т.ның (ш.и. Әстерхан, Себер, Кырым Т.ының) һәм нугайларның төрле төркемнәре арасында татар (төрки-монгол) ыруглары — табын, катай, таз, найман, коңграт / кордак, кереит, карагай, елан, тугыз нәселләре һ.б. иң югары урынны билиләр. Алар составына кергән төркиләшкән угор төркемнәре иштәк /үштәк/ остяк атамаларын алалар, угор тамырлы башка атамалар — Урал алдындагы элеккеге кабилә исемнәре (истяк, бикатин, юрма, гайна, уват, супра һ.б.) — башлыча, топонимикада гына саклана.

Бер үк вакытта бердәм дәүләт кысаларында үзенчәлекле төрки-татар этник бердәйлеге урнашу процессы бара. 14 йөз башында, Үзбәк хан идарә иткән чорда (1312–41) Җүчи Олысында дәүләт диненә әверелгән исламның таралуы, ш.у. норматив әдәби тел (Идел буе төрки теле) булдырылу, язу һәм әдәбият үсеше Алтын Урда халкының туплануында мөһим элемент була. Хәрби-йомышлы аксөякләр арасында Җүчиләрнең мифологемаларын һәм символларын, өлешчә дөньяга мөселманча карашларны үз эченә алган, этник кысалардан өстен империячел мәдәният формалашу әлеге мәдәни-тарихи процессларның үзәген тәшкил итә. Болар барысы да Алтын Урда аксөякләренең социомәдәни туплануына һәм 14 йөздә Җүчи Олысының ыруг-кабилә олыс системасына кергән, башлыча, мөселман аксөякләреннән торган яңа «Т.» этносоциаль берлегенең барлыкка килүенә китерә. Әлеге аксөякләргә Идел-Урал төбәгендә биләмәгә җирләр һәм олыслар бирелә, җирле аксөякләр аларның состав өлешенә әверелә. Бу хакта тел, топонимика һ.б. материаллар, аерым алганда, Идел буе — Урал алды Т.ы арасында (кайчак топономикада, аксөякләрнең шәҗәрәләрендә) коңграт, бөркүт, мең, токуз, токсоба, кереит, катай, табын, кыпчак, алат, бодрак кебек ыруг атамалары барлыкка килүе шаһитлек итә. Салымнар түләүче авыл һәм шәһәр халкы (*кара халык*) үзатама сыйфатында еш кына топонимнардан ясалган тәхәллүсләр куллана (әл-Болгари, әс-Сараи, Мүн-Буләр һ.б.).

15 йөз уртасында Алтын Урда таркалганнан соң әлеге дәүләтнең ахыргы чорында барлыкка килгән сәяси берләшмәләр составында локаль үзатамалары булган яңа этносәяси берлекләр формалаша башлый, ә «Т.» термины аларның клан системасына берләшкән һәм «йомышлы татарлар» буларак исемләнгән хәрби-йомышлы аксөякләр катлавы өчен



Җамигъ мәчет (С.С.Айдаров реконструкциясе). 10–11 йөзләр. Биләр.



Ук савытының тышы. Сырлы сөяк. Җүчи Олысы. 13 йөз.

гомуми билгеләмәгә һәм үзатамага әверелә. Бу этнотерр. төркемнәрнең формалашуы 15–16 йөзләрдә, Алтын Урда җирлегендә барлыкка килгән төрки-татар дәүләтләре (Олы Урда, Нугай Урдасы, Себер, Казан, Кырым, Әстерхан һәм Касыйм ханлыклары) кысаларында, кайчакта алардан читтә (Бөек Литва кенәзлегендә, Госманлы империясенең Буджак даласында) тәгалләнә. Шулай да уртак дәүләти һәм этномәдәни традицияләр элеккечә үк халыкның бөтенлеге идеясе саклануның мөһим сәбәпләренең берсе булып кала. 16 йөзнең 2 нче яртысында Казан, Әстерхан һәм Себер ханлыклары Рус дәүләте тарафыннан яулангannan соң Т.ның төрле этнотерр. төркемнәренең күчеш процесслары һәм үзара бәйләнешләре көчәя. Башлыча, мишәрләрдән һәм Казан татарларыннан торган *йомышлы татарларның* күп кенә төркемнәрен күчереп утырту нәтиҗәсендә Идел-Урал төбәгендә һәм Себердә татар халкының төрле этник төркемнәре тел һәм мәдәният җәһәтендә үзара якынаялар. Бу процесс 17 йөз ахырында Идел буе — Урал алды Т.ы төркеме оешкан Идел-Урал төбәгендә аеруча интенсив төс ала. Бу төркемнең тиз формалашуына Алтын Урда һәм татар ханлыклары чорларында барлыкка килгән уртак тарихы, дине, тел һәм мәдәни-көнкүреш традицияләре, ш.у. христианлаштыру, руслаштыру сәясәтенә һәм милли изүнең башка төрләренә каршы тору объектив зарурлыгы этәргеч бирә. Т.ның төрле төркемнәренең этномәдәни үсеше үзенчәлекләренең берсе, аларның үзара якынаюының шарты һәм нәтиҗәсе бер үк диндә булуны аңлаудан, гомуми «мөселманнар» конфессионимы нығып урнашудан һәм кулланылудан гыйбарәт була.

19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында Россиядә буржуаз мөнәсәбәтләрнең тиз үсеше Т.ның Россия җәмгыятенең иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни-мәгариф тормышында активлашуына китерә. Бу чорда буржуаз үзгәртеп корулар барышында «Т.» этнонимы нигезендә этник үзаңның яңа, милли тибы формалаша, ш.у. Т.ның төрле Европа һәм Себер субэтник, этнографик төркемнәренең туплануы көчәя. Гомумтатар вакытлы матбугаты, татар конфессиональ мәгарифенең яңа ысуллы системасы, заманча әдәби тел, дөньяви әдәбият, милли китап басу яралуга китергән татар җәмгыятенең патриархаль нигезләрен үзгәртеп кору идеологиясе



**Татарлар**. 1. Крәстияннәр. 20 йөз башы; 2. Һөнәрчеләр. 20 йөз башы; 3. Татар аяк киемнәре сатучы сәүдәгәр кибете. 20 йөз башы фоторәсеме; 4. Авыл мулласы. 19 йөз ахыры. Казан губернасы Казан өязе Әтнә авылы; 5. Татар кавалерия полкы кавалеристлары төркеме. 1919; 6. Татар сәүдәгәре гаиләсе. 20 йөз башы; 7. Сәүдәгәр Юнысовлар гаиләсе. 20 йөз башы фоторәсеме.

(к. *Җәдитчелек*) татар буржуаз милләте оешу өчен төп шарт була.

Төрки-татарларның барлык төп этнотерр. төркемнәре тарафыннан бердәм татар үзаңының үзләштерелүе һәм «Т.» этнонимының ныгып урнашуы — 20 йөз башына татар милләте туплану процессы төгәлләнүенең бер чагылышы. СССРда 1926 да уздырылган халык исәбен алу мәгълүматлары буенча, илнең Европа өлешендә яшәгән татарларның 88% ы үзләрен «Т.» дип яздырган, аларның кечкенә өлеше генә этноним сыйфатында локал атамалар кулланган: Идел-Урал Т.ы — мишәр, керәшен (аларның бер өлеше — нагайбәк), типтәр; Әстерхан Т.ы — нугай, карагаш; Себер Т.ы бохарлык, төмәнлек, бараба, тубыллык буларак теркәлгән. Бу Т.ның бер өлешендә патриархаль һәм этнотерр. традицияләрнең аерым формалары саклануын күрсәтә.

Бер үк вакытта яңа татар идеологиясе оешу процессы бара. Аның төп нигезләмәләре Ш.Мәрҗани тарафыннан формалаштырыла. Аның фикеренчә, татар этносы җитлегүенең төп элементы татар ханлыкларында да саклanган Алтын Урда традицияләреннән гыйбарәт булган. Мәрҗани идеяләре И.Гаспринский, Р.Фәхретдин, Һ.Атласи, Г.Ибраһимов, Г.Исхакый һ.б. хезмәтләрендә үстерелә. Бу идеология Россиянең мөселман төрки-татар халкы арасында киң тарала. Т. тупланып яшәгән урыннарда һәр җирдә дә бердәм этномәдәни һәм этносәяси үзаңны үстерүне төп максат иткән төрле мөселман хәйрия оешмалары төзелә. 1906 да «*Иттифак әл-мөслимин*» сәяси партиясе оештырылу һәм аның җитәкчеләренең Россиянең барлык чакырылыш Дәүләт Думасында даими катнашуы (С.Алкин, Ә.Әхтәмов, Ибн. Әхтәмов, С.Максуди һ.б.) — гомумтатар идеологиясен гамәлгә ашыруның иң югары формасы була. Ул партиянең программасында татар халкының төп таләпләре алга сөрелә: киң милли-мәдәни автономия, ш.и. мәгариф һәм дин өлкәсендә автономия бирелү.

1905–07 еллардагы Революция чорында, башта милли-мәдәни автономия рәвешендә, «татар дәүләтчелеге» идеясе үсеш ала, «Иттифак әл-мөслимин»нең җирле бюролары аның прототиплары була. Патша бәреп төшерелеп, хакимияткә вакытлы хөкүмәт килгәннән соң (1917), бу сәяси хәрәкәт әзлекле рәвештә Т.ның киң милли-мәдәни автономиясен төзүгә омтыла. 1918 дә Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Милләт Мәҗлесе Идел-Урал Штатын төзү турында карар кабул итә. Ләкин татар милли-демократик көчләренең аны гамәлгә ашыру омтылышы 1918 нең 1 мартында совет хакимияте тарафыннан өзелә (к. *Болак арты республикасы*). 1918 дә РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты, аңа алмаш рәвешендә, милли большевиклар (М.Вахитов, М.Солтангалиев, Г.Ибраһимов һ.б.) басымы астында Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасын төзү проектын тәкъдим итә (гамәлгә ашырылмыйча кала). 1920 дә РСФСР составында Татарстан АССР төзелә, бу процесс татар хәрәкәтен халыкның киң хуплавы, аның үз милли мәнфәгатьләрен сәяси алымнар б-н якларга әзер булуы б-н бәйле. Автономияле респ-ка составына Советлар Россиясендәге татарларның яртысыннан бераз гына кимрәк өлеше (3,3 млн. кешедән 1459,6 мең кеше) кертелә. ТАССРның чикләрен нигезсез билгеләү һәм татар халкын ясалма рәвештә бүлгәләү нәтиҗәсендә Т. тупланып яшәгән, терр-яләре яңа оештырылган респ-ка чикләренә орынып торган өязләр дә (Бәләбәй өязе, халкы — 671 мең кеше, татарлар 62%, башкортлар 4,5 %; Бөре өязе, халкы — 626 мең кеше, татарлар 55%, башкортлар 4,4%) аның составына керми кала. Татарстан респ-касында Т. халыкның 50% ы чамасын гына тәшкил итә.

ТАССР төзелү б-н Т.ның зур өлеше милли мәгариф һәм мәдәният системасын туган телләрендә үстерү мөмкинлегенә ирешәләр. Казан ханлыгы 1552 дә яуланганнан соң беренче тапкыр, рус теле б-н беррәттән, татар теле дәүләт теленә әверелә. Гуманитар фәннәр өлкәсендә фәнни тикшеренүләр оештыру өчен респ-када *Академүзәк* ачыла. Дәүләт аппаратында *төпләндерү* сәясәте һәм эш кәгазьләрен алып баруда татар телен киң куллanышка кертү милли мәдәниятнең тиз үсешенә һәм халыкның массачыл рәвештә белем алуына булышлык итә. Республикада милли кадрлар әзерләү һәм аларны дәүләт, партия, профсоюз, мәхкәмә һ.б. органнарда вазифаларга билгеләү, татар телен дәүләт һәм җәмәгать идарәсе органнарында, мәдәни-массачыл эш учреждениеләрендә кулланышка кертү программасын гамәлгә ашыру буенча эшләр башкарыла.

1920–30 елларда актив рәвештә татар интеллигенциясенең яңа буыны формалашу процессы бара (сынлы сәнгать, опера, балет һ.б.), гуманитар фәннәрнең яңа тармаклары булдырыла, ш.у. ТАССРда һәм илнең башка төбәкләрендә татар теленең позициясен ны-








8. Ф.Аитова мәктәбе укучылары. 1919; 9. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллимнәре. Казан, 1912; 10. Россия Дәүләт Думасы депутатлары һәм «Мөселман хезмәт таифәсе» әгъзалары (сулдан уңга): К.Хәсәнов, Һ.Атласи, Х.Мәсәгутов, Ф.Туктаров; 11. Шәрекъ клубы кыллы музыка кораллары оркестры. Казан. 1910; 12. Татар актёрлары төркеме. Казан. 1918; 13. Татар язучылары һәм публицистлары (сулдан уңга): В.Бәхтияров, К.Бакир, Ф.Әмирхан, И.Әмирхан, Г.Тукай. 1908.

гыту сәясәте уздырыла. 1926–29 да татар алфавитын латин язуына күчерү гамәлгә ашырыла. 1939 дагы халык исәбен алу мәгълүматлары буенча СССРдагы татар халкының укый-яза белү дәрәҗәсе шактый югары булуы ачыклана: 50 яшьлекләр һәм өлкәнрәкләр төркемендә укый-яза белүчеләрнең өлеше — 48,3%, 20–49 яшьлекләрдә — 78%, 9–19 яшьлекләрдә 96% тәшкил итә. 1930 еллар уртасында ТАССРдагы 3339 гомуми белем бирү мәктәбенең 1738 е татар мәктәпләре була (50% тан артык). 1939 елга респ-ка мәктәпләрендәге барлык укучыларның 48,7% ы татар телендә белем ала. 1939–40 елларга Т.ның өлеше югары уку йортлары студентлары арасында — 17,2% ка, урта техник уку йортларында укучылар арасында 49,5% ка җитә (ТАССР буенча мәгълүматлар).

Шул ук вакытта, СССР төзелгәннән соң (1922), ил җитәкчелегенең дәүләт милли сәясәте Т.ның этносәяси, милли-үзенчәлекле үсешен чикләү ягына борыла һәм халыкларуртак уазаңының милли-дөньяга караш өлкәсенә максатчыл йогынты ясый башлый. Совет түрәләре, империячел сәясәтнең рев-циягә кадәрге постулатларына һәм Т.ның традицион милли йолаларының билгеле бер сыйфатларына таянып, бу сыйфатларны мәкерле кулланып, яңа, татар этник ментальлегеннән һәм социаль-гаилә нигезләреннән үзгә этномәдәни формалар оештыра башлыйлар (к. *Культура революциясе*).

1937–38 дәге «Зур террор» — Т. тормышында яңа фаҗигале чор: буржуаз-милләтчел, солтангалиевчел, троцкийчыл, бухаринчыл һ.б. оешмаларда тору турындагы ялганга корылган эшләр, корткычлыкта гаепләүләр һ.б. буенча Т.ның меңнәрчә сәяси, фәнни һәм иҗади интеллигенция вәкилләре эзәрлекләүләргә һәм кулга алынуларга дучар ителә. Массачыл репрессияләр татар сәяси һәм интеллектуаль элитасының сәләтле өлешенең кырылуына яки төрмәләргә һәм концлагерьларга ябылуына китерә (1942 нең 1 гыйнварына ГУЛАГ системасында 29,1 мең татар тотыла). Бер үк вакытта рус алфавиты гамәлгә кертелү нәтиҗәсендә (1939) халык тормышындагы тарихи-мәдәни дәвамлылык бозыла.

Бөек Ватан сугышы елларында, Төньяк Кавказ һәм Кырымның мөселман халкын сөрү чорында Т.га идея-сәяси һәм этномәдәни басым көчәя. ВКП(б) ҮКның «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында» карары (1944) татар милли мәдәнияте һәм фәне үсешенә гаять зур зыян китерә. Шундый ук юнәлештәге махсус чараларның тагын берсе — СССР ФА Тарих һәм филос. бүлегенең Мәскәүдә СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты б-н берлектә оештырылган сессиясе (1946 ның 25–26 апреле). Ул Т.ның килеп чыгышын бары тик болгар теориясе кысаларында өйрәнүне рәсмиләштерә (к. *СССР ФА фәнни сессиясе*). Т.ның мәнфәгатьләрен чикләү юлында ясалган чираттагы адым 1952–53 тә ТАССРны Бөгелмә, Казан һәм Чистай өлкәләренә бүлүдән гыйбарәт була (1953 нең апрелендә И.В.Сталин вафатыннан соң алар бетерелә).

«Хрущёв җепшеклеге» чорында Татарстанның аеруча актив иҗат һәм фән интеллигенциясе вәкилләре милли яңарыш өчен идея көрәше башлыйлар. 1954 тә алар тарафыннан КПСС ҮКына хат җибәрелә, хатта милли мәдәният үсешен ясалма тоткарлау, татар мәктәпләренең саны кимеүе, татар-рус мөнәсәбәтләрен бозып тасвирлау, Россия дәүләте тарихында татар халкының ролен кечерәйтү күрсәтелә, ш.у. милли топонимика проблемалары күтәрелә, Татарстанга союздаш респ-ка статусы бирелергә тиешлеге турындагы мәсьәлә көн тәртибенә куела. 1950 елларның 2 нче яртысында милли интеллигенциянең активлыгы сизелерлек көчәя һәм совет җитәкчелеге татар җәмгыятендәге киеренкелекне киметү өчен чаралар күрергә мәҗбүр була. Нәтиҗәдә 1957 дә татар телен камилләштерү буенча орфография һәм терминология комиссияләре эшләрен кабат башлыйлар, 1958 дә КПССның Татарстан өлкә ком-ты «Татар гомуми белем бирү мәктәпләренең торышы һәм аларның эшен яхшырту буенча чаралар турында» карарын кабул итә, 1958 нең октябрендә мәдәният хезмәткәрләренең 1 нче съезды, 1957 нең 24 маенда — 2 июнендә *Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы* уздырыла.

1950–80 елларда татар мәдәнияте һәм халык мәгарифе үсеш кичерә, татар фәнни, техник һәм иҗади интеллигенциясенең саны күпкә арта. 1970 тә СССРда югары һәм махсус урта белемле белгечләр арасында Т.ның чагыштырмача өлеше 1,5% ка җитә (бу күрсәткеч әзәрбайҗаннарның, казакъларның һәм литвалыларның шундый ук күрсәткечләреннән югарырак). СССР югары уку йортлары студентлары арасында 1956–57 дә 25,3 мең, 1974–75 тә 99,8 мең Т. була. 1965/66 уку елына аларның өлеше ТАССР югары уку йортлары студентлары арасында 34,6% ка, урта техник уку йортлары укучылары арасында 35% ка җитә. 1955 ел мәгълүматлары буенча, СССРда фәнни хезмәткәрләр арасында 2142, 1975 тә 15920 Т. исәпләнә. 1970 тә Татарстанда аларның өлеше фәнни хезмәткәрләр









Татарлар һиҗрәте. 1. Финляндия татарлары – кибет хуҗалары. 1920 еллар; 2. Голҗа шәһәре татар мәктәбе укучылары, ата-аналар комитеты әгъзалары һәм укытучылар. Кытай. 1938; 3. «Идел-Урал» төрки-татар җәмгыяте әгъзалары. Токио. Япония. 1934; 4. Татарлар һиҗрәте вәкилләре С.Максуди, Й.Акчура. Стокгольм. Швеция. 1918.

арасында 29,3%, аспирантлар арасында 29,6%, фән докторлары һәм кандидатлары арасында 30,1% тәшкил итә. 1987 дә Т.дан 4055 галим исәпләнә (гомуми санның 34,9% ы), алар арасында фән докторларының һәм кандидатларының өлеше 44,8% була (руслар арасында шул категория буенча күрсәткечтән беркадәр югарырак). 1990 ел мәгълүматлары буенча, респ-кадагы фән докторлары арасында Т.ның өлеше 32% тәшкил итә, ш.и. иҗтимагый-гуманитар фәннәр буенча 50% тан арта. 1989 да Татарстанның югары уку йортлары профессорлар-укытучылары составында 2481 татар исәпләнә (гомуми санның 36,6% ы).

Шул ук вакытта үзәк җитәкчелек басымы астында 1960–70 елларда орфография һәм терминология комиссияләре таратыла, рус мәктәпләрендә татар телен укыту туктатыла, Т. тупланып яшәгән урыннарда татар мәктәпләрен һәм сыйныфларын кыскарту процессы башлана. 1980 еллар башына респ-ка милли мәктәпләрендә укучы Т.ның саны кискен кими: аларның өлеше 1970/71 уку елында – 29,1% ка, 1980/81 уку елында – 18,6% ка, 1987/88 уку елында 11,8 % ка кыскара. 1986 да татар телендә 181 исемдә китап нәшер ителә (чагыштыру өчен: үзбәк телендә – 955, казакъ телендә – 676, әзәрбайҗан телендә – 869, грузин телендә 1764 исемдә китап басыла). Вакытлы матбугатта да шундый ук хәл күзәтелә: 1980 дә татар матбугатының бер санлык тулай тиражы газеталар буенча 870 мең һәм журналлар буенча 1394 данә тәшкил итә (казакъ телендә – 2014 мең газета һәм 2067 мең журнал, тиңдәшле рәвештә үзбәк телендә 4796 мең һәм 4509 мең, литва телендә 2035 мең һәм 1937 мең, грузин телендә 3128 мең һәм 1054 мең данә газета-журналлар чыгарыла). Ассимиляция нәтиҗәсендә Т.ның демографик үсешендә дә тискәре күренешләр күзәтелә. Демографлар мәгълүматлары буенча, 1979–89 да СССРда татар халкының ассимиляцияләнү сальдосы 327 мең кеше чамасы тәшкил итә. Бу чорда Т. арасында тел процесслары хәвефле төс ала: мәктәпләрдә укучы татар балаларының 28,3% ы – рус телендә генә, 42,8% ы – татар һәм рус телләрендә, өлкәннәрнең 18% ы – рус телендә генә, 37% ы бер үк вакытта рус һәм татар телләрендә сөйләшәләр (мәгълүматлар Татарстан буенча бирелә). Ассимиляция процессларының нәтиҗәләре халык санын алу мәгълүматларында да чагыла: Россиядә татар телен туган тел дип исәпләүчеләрнең өлеше 1970 тәге 89,2% тан 2002 дә 80,8% ка кадәр кими.

20–21 йөзләр чигендә, СССР таркалу нәтиҗәсендә, Т.ның милли мәнфәгатьләренең суверенлашуы өчен көрәш барышында, татар халкының этносәяси һәм интеллектуаль элитасы Т.ның төрле этнотерр. төркемнәренең мәдәни-тел ихтыяҗларын канәгатьләндерүнең хокукый һәм оештырылу механизмнарын эшли. ТР Конституциясенең 14 нче маддәсендә респ-каның «ТРдан читтә яшәүче татарларга милли мәдәниятне, телне үстерүдә, үзенчәлекләрен саклауда ярдәм күрсәтүгә» омтылышы игълан ителә. «2004–2013 елларда ТР дәүләт телләрен һәм ТРдагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча ТР Дәүләт программасы»нда РФ төбәкләрендә, БДБ илләрендә, Т. тупланып яшәгән урыннарда татар телен саклауга һәм үстерүгә зур игътибар юнәлтелә. Татарстанның төбәкләрдәге татар җәмгыятьләре б-н эшчәнлек җәелдерүенең төп механизмнары сыйфатында зарури очракларда уртак мәдәни-мәгариф программаларны, Татарстан сәүдә вәкиллекләре кысаларында хезмәттәшлекне, аерым ведомстволар (РФ Тышкы эшләр министрлыгы) җирлегендә бергә эшләүне, федераль милли бәйрәмнәрне (*Сабан туе*), җыр, фольклор, театр һ.б. фестивальләрне уздыруны күздә тоткан төбәкара хезмәттәшлек турындагы шартнамәләр тәкъдим ителә. Шул ук юнәлештә, башлыча, татар дини мәхәлләләрен берләштергән үзәкләштерелгән мөселман оешмалары (Үзәк мөселман Диния нәзарәте, Россия Мөфтиләр Шурасы һ.б.) эшли. Совет дәвереннән соңгы чорда Россия төбәкләрендә, аеруча Татарстанда, милли мәктәпләрнең һәм укыту планнарында татар этномәдәни компоненты булган мәктәпләрнең саны шактый арта. Төрле типтагы милли мәктәпләр ш.у. РФнең кайбер шәһәрләрендә (Мәскәү, Саратов, Ульяновск, Димитровград, Уфа һ.б.) оештырыла. 2006/07 уку елына Татарстанда милли мәктәпләрдә татар милләтеннән булган укучыларның яртысыннан күбрәге белем ала, рус телле гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучы татар балаларының барысы да диярлек туган телне өйрәнә. Соңгы елларда РФ Үзәк хакимият органнары мәгариф өлкәсендә милли-төбәк компонентларын, ш.и. рус булмаган халыкларның телләрен өйрәнүне чикләүгә йөз тота.

Т. – югары үсешле фәнгә һәм һөнәри мәдәниятка ия халык. Ул РФдәге һәм чит илләрдәге күп кенә башка халыклар б-н тыгыз икътисади һәм мәдәни бәйләнештә тора. Үсеш алган структурасы булган, гуманитар юнәлештәге ин-тларны (*Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты*, *Тарих институты*, Археол. ин-ты) үз эченә алган *Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе* төзелү милли тел, әдәбият, мәдәният, тарих, респ-ка икътисади яңарышында мөһим роль уйный. Фәнни тикшеренүләр кысаларында татар галимнәре гуманитар һәм гамәли белемнәр өлкәсендә, аерым алганда, милли тарих, тел белеме, әдәбият белеме һәм мәдәниятне өйрәнү (культурология) б-н бәйле юнәлешләрдә уңышлы рәвештә эш алып баралар.

Академия ин-тларының гуманитар фәннәр галимнәре икетелле һәм диалектологик сүзлекләр, татар әдәбияты тарихын (6 томда) һәм фольклорын (12 томда), 7 томлык Т. тарихын, татар һәм рус телләрендә 6 шар томлык Татар энциклопедиясен һ.б.ны басмага әзерлиләр һәм нәшер итәләр. Татар галимнәренең төрле фәнни белемнәр тармакларында: физика һәм физика химиясе (К.Ә.*Вәлиев*, Ренад З.*Сәгъдиев*, Роальд З.*Сәгъдиев*, К.М.*Салихов*, Р.А.*Сюняев*, М.М.Зарипов, И.Б.*Хәйбуллин*, И.Г.Гарифуллин), техника (Р.Ф.*Ганиев*, Ю.Г.*Нәҗмиев*, Р.И.*Нигъмәтуллин*), химия (Г.Х.Камай, Г.Г.*Вәлиев*, Х.М.*Миначёв*, С.Р.*Рәфыйков*, Р.С.Сәйфуллин), математика (Д.Ә.*Гобәйдуллин*, И.Г.*Ибраһимов*, М.Ә.*Илһамов*), медицина (Р.С.*Акчурин*, Н.Х.*Әми*-

*ров*), гуманитар фәннәр (Ш.*Мәрҗани*, М.Г.*Гәрәев*, А.Х.*Халиков*, И.Р.*Таһиров*, М.Г.*Госманов*, М.З.*Зәкиев*, М.И.*Мәхмүтов*) өлкәләрендәге казанышлары киң таныла. Татар әдәбияты һәм мәдәнияте эшлеклеләренең (шагыйрьләр Г.*Тукай*, М.*Җәлил*, язучылар Г.*Ибраһимов*, Г.Исхакый; композиторлар С.Җ.*Сәйдәшев*, Н.Г.Җиһанов, С.Г.*Садыйкова*, С.Ә.*Гобәйдуллина*, Ф.З.*Яруллин*, Р.З.Ахиярова, Р.Ф.Кәлимуллин, М.М.Шәмсетдинова; дирижёрлар Ф.Ш.*Мансуров*, Р.Ә.*Мартынов*, М.Ә.Тәминдарова; татар җырларын башкаручылар Р.В.*Ваһапов*, И.Г.*Шакиров*, Ә.А.*Авзалова*, С.З.Фәтхетдинов; сәхнә сәнгате эшлеклеләре Р.Х.*Нуриев*, Л.Г.*Кустабаева*, Р.М.Гарипова, И.Җ.*Мөхәммәдов*, А.Ә.*Шаһиморатова*, А.Э.Гарифуллина; рәссамнар С.С.*Ахун*, Ч.Г.*Әхмәров*, Х.Г.Якупов, Л.Г.Фәттахов, Б.И.*Урманче*, И.К.*Зарипов*, К.В.*Муллашев* һ.б.) иҗаты дөньякүләм танылу ала. Татар спортчылары — Олимпия һәм дөнья чемпионнары, төрле ярышларда призлар алучылар (Ш.*Сафин*, А.*Кабаева*, Л.Үтәшева, Р.*Дасаев*, И.*Гыймаев*, З.*Билалетдинов*, М.*Сафин*, Д.*Сафина*, А.Галләмова) исемнәрен дөнья күләмендә беләләр. Татар халкы вәкилләре Россия (М.Х.Солтангалиев, Ф.Ә.*Табиев*, Г.И.*Усманов*, М.Ш.*Шәймиев* һ.б.), Төркия (С.Н.*Максуди*, Ә.*Вәлиди*, Ә.*Мәңгәр*), Кытай (Б.Шаһиди) иҗтимагый-сәяси тормышында күренекле урын билиләр. Ватан алдындагы хезмәтләре өчен дистәләрчә мең татар СССР, РФ орденнары һәм медальләре б-н бүләкләнә, дәүләт бүләкләренә һәм мактаулы исемнәргә, ш.и. Советлар Союзы Герое (233 кеше), Россия Федерациясе Герое (7 кеше), Социалистик Хезмәт Герое (133 кеше) исемнәренә лаек була. Татар халкының 100 дән артык вәкиленә генерал, ике кешегә (М.Г.Гәрәев, Р.Г.Нургалиев) армия генералы дәрәҗәсе бирелә.

**Традицион яшәү урыннары, хуҗалык итү, матди мәдәният һәм көнкүреш мәдәнияте.** Хәзерге Т. бабаларының озакка сузылган миграция процесслары, аларның Россиянең зур киңлекләрендә таралып урнашуы, башка халыклар (руслар, марилар, чуашлар, удмуртлар, башкортлар һ.б.) б-н үзара бәйләнышлары, татар халкы тупланып яшәгән төрле районнардагы табигать-климат һәм социаль-икътисади шартларның үзенчәлекләре традицион мәдәният үсешенә төрле яклап йогынты ясый. Т. үз тарихларының элгәреге чорларында, башлыча, төркиләр һәм фин-угорлар, өлешчә руслар мохитендә яшәгәнгә күрә, аларның мәдәниятендә күп кенә яңа, җирле төп халыклардан үзләштерелгән элементлар барлыкка килә. Татар халкы тупланып яшәгән урыннарда Т. башка халыклар, башлыча, руслар, чуашлар, марилар һәм удмуртлар б-н көнкүрештә этномәдәни җәһәттә бер-берсенә тәэсир итешәләр. Җирле шартларга яраклашып, көнкүрештә яңа үзенчәлекләргә ия булган хәлдә Т. үзләренең традицион мәдәният нигезләрен (игенчелектә, торакларда, туклануда һәм ризыкларда, кием-салымда, йолаларда һ.б.да) саклыйлар һәм күрше халыкларның көнкүреш мәдәниятенә йогынты ясыйлар. Бу процесс Т.ның башка төрки халыклар, ш.у. җирле фин-угор халкы б-н күптәнге тел һәм мәдәният кардәшлек якынлыгы нәтиҗәсендә җиңеләя.

19 йөздә — 20 йөз башында Т.ның икътисади тормышы нигезен *игенчелек* тәшкил итә (терлекчелек ярдәмче тармак була, Әстерхан һәм Себер Т.ында — балыкчылык, Себер Т.ында һәм Урал алды мишәрләрендә — аучылык, Әстерхан Т.ында бакчачылык шундый ук урынны били). Авыл халкының бер өлеше кәсепчелек һәм һөнәрчелек — күн аяк киемнәре тегү, зәргәрчелек һ.б. б-н шөгыльләнә. Казан, Уфа, Оренбург һ.б. губерналардагы татар авыллары кустарь кәсепчелек һәм сәүдә үзәкләре булалар. 18–19 йөзләрдә татар сәүдәгәрләре Урта Азия халыклары б-н сәүдә-арадашчылык эшләрендә мөһим роль уйныйлар. Казан Т.ы күн (*сафьян, юфть*), сарык тиресе, йон эшкәртүдә югары дәрәҗәдәге осталыклары б-н дан казаналар. 18–19 йөзләрдә халык кәсепләре җирлегендә Т.да киез итек-киез басу, тире иләү, туку, читек тегү һәм укалап чигү-тегү мануфактуралары, 19 йөздә күн, постау пр-тиеләре һ.б. барлыкка килә. Себер Т.ы күн, курыс эшкәртү, баулар, тал чыбыгыннан әрҗәләр, ятьмәләр үрү, арбалар, чаналар, көймәләр, чаңгылар, каен тузыннан һәм агачтан төрле эшләнмәләр ясау б-н шөгыльләнәләр. Идел буендагы күп кенә татар крәстияннәре читкә китеп, игенчелектә, Донбасстагы күмер шахталарында, Урал алдындагы алтын приискаларында, Әзәрбайҗанда нефть чыгаруда эшлиләр (к. *Эшчеләр сыйныфы*), юл йөртү кәсебе б-н шөгыльләнәләр (к. «*Барабыз*»).

19 йөздә — 20 йөз башында игенчелектә өч басулы чәчү әйләнешле пар системасы аеруча киң тарала. Идел буеның һәм Урал алдының далалы көньяк-көнчыгыш р-ннарында игенчелектә җирдән файдалануның болгар-татар формаларының элгәреге чорларына хас булган яткын-кысыр җирләр системасының кайбер сыйфатлары саклана. Анда арыш, солы, арпа, бодай, борчак, ясмык, тары, борай, яшелчәләр (башлыча, бүлбеләр һәм тамыразыклар), җитен һәм киндер, Әстерхан Т.ында җиләк-җимеш культуралары игелә. Игенчелекнең традицион рәвеше төрле табигый зоналарда бер-берсеннән аерыла. Көнчыгыш Европаның урман-далалы р-ннарында Т. туфракны күчерелмә калаклы ике тешле сука, далалы р-ннарда болгарлар заманыннан ук мәгълүм ике көпчәкле авыр агач *сабан* б-н эшкәртәләр. 19 йөз уртасыннан Урал алдында татар крәстияннәре арасында суканың камилләштерелгән төрләре тарала. Җир сөрүдә һәм йөкләр ташуда, башлыча, атлар файдаланыла. Т.ның һәм җирле халыкларның тырмалау (агач тырма, сирәгрәк тимер рамлы тырма) һәм игеннәрне урып-җыю (урак, соңрак чалгы), ашлык сугу (чабагач) кораллары бертөрле була. Кырда көлтәләр эскертләргә, сосланнарга куела. Ашлыкны сугу алдыннан көлтәләр рус тибындагы буралы әвендә яки гадәти әвендә — шәшедә киптерелә. Агач көрәк б-н җилгәрелгән ашлыкны еш кына зур түгәрәк иләкләрдә (тагаракларда) чистарталар. Он җил яки су тегермәннәрендә, ш.у. кул тегермәне ярдәмендә тартыла; ашлыкны ярмага ваклау өчен агач киләләр, Т. яшәгән аерым урыннарда кул көченә нигезләнгән яки механик яргычлар файдаланыла.



Авыл урамы. 1970 еллардагы фоторәсем.

Идел буе–Урал алды һәм Себер Т.ында яшелчә бакчачылыгы мөһим роль уйнамый. 19 йөздән Т.ның күпчелегендә бәрәңге төп бакча үсемлегенә әверелә. Урал алдының көньягында һәм Әстерхан төбәгендә бакчачылык зур әһәмияткә ия була. Әстерхан Т.ы яшелчә бакчаларында — суган, кәбестә, помидорлар, бакчаларда — карбызлар, җиләк-җимеш бакчаларында алмалар, виноград, чия, шәфталу, слива, айва, алыча үстерәләр.

Терлекчелек көтүлекле-аранлы рәвештә үсеш ала: Т. — гадәттә, мөгезле эре һәм вак терлек, атлар, керәшен Т. дуңгызлар да асрыйлар. Оренбург һәм Әстерхан Т.ында терлекчелек игенчелек кебек үк мөһим урын били. Һәр төбәктә дә кош-корт — тавыклар, казлар, үрдәкләр асрыйлар.

Россия терр-ясендә татар торулыклары төрле тарихи, табигый-геогр. һәм этник шартларда нигезләнәләр. Килеп урнашу үзенчәлекләре турыдан-туры торулыкларның типлары һәм аларның планлашу структурасы формалашуга йогынты ясый. Кама алды һәм Урал төбәге р-ннарының күпчелеге өчен — иңкүлекләрдә һәм калкулык битләрендә урнашкан аз хуҗалыклы авыллар, Т. таралып урнашкан урман-далалы һәм далалы җирләр өчен тигезлектә урнашкан күп хуҗалыклы авыллар хас. Кагыйдә буларак, торулыклар елгалар һәм инешләр агымы буйлап, күлләр, чокырлар һәм сызалар ярлары тирәли, юллар кырыенда төзеләләр. 17–18 йөзләрдәге ирекле колонияләштерү процессында стихияле рәвештә барлыкка килгән татар торулыкларының планы системага нигезләнми. Елгалар яки почта юлы буйлап урнашкан авыллар, гадәттә, бер рәт яки урам булып сузылалар. Урман-далалы һәм далалы җирләрдәге авылларның күбесе учаксыман — аерым торулыклардан торган сирәкләнгән челтәр рәвешендә була. 18 йөз ахырында — 19 йөз башында татар авылларының планлаштыруда урамлап-тәртипсез, урамлап-оялап, урамлап-радиаль, урамлап-кварталлап һәм рәтләп урнашу төрләре өстенлек итә. Т.ның торулыкларына йортларның тыгыз урнашуы, урамнарның туры булмавы, еш кына тупик-

лы тыкрыклар б-н тармаклануы хас. Авылларның урамлап планлашуында кардәш төркемнәрнең, кайбер очракларда берничә гаиләнең бер җирдә тупланып урнашуы күзәтелә. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан Идел буе–Урал алды Т.ы авылларының урамнары планлашуы даимирәк рәвешкә керә башлый. Себер Т.ында «ике бүлемле» торулыклар — кышлыклар һәм җәйләүләр таралыш ала. Кагыйдә буларак, эре торулыкларның үзәгендә дини һәм җәмәгать биналары, кибетләр, сату урыннары, базар мәйданнары, ш.у. өстен катлау вәкилләренең (руханилар, таза тормышлы крәстияннәр, сәүдәгәрләр һ.б.) утарлары урнаша. Анда базарлар, волость һәм авыл җыеннары уздырыла, ярминкәләр һәм җыен вакытындагы күңел ачулар оештырыла (к. *Җыен*). Т. тупланып яшәгән күп кенә урыннарда авыл кырыенда тегермәннәр, җир өстенә чыгарып салынган яки ярымземлянка тибындагы мунчалар һ.б. урнаша. Урманлы җирләрдә авылларның кырыйлары киртәләп алына, анда көтү чыгарыла. Урам башына басу капкасы куела. Татар авылларының күпчелеге аларны нигезләүчеләрнең исемнәре б-н яки җирнең элеккеге хуҗалары фамилияләренә, ш.у. җирле топонимикага (гидронимикага), өлешчә халыкның шөгыле төренә нисбәтле рәвештә атала.

Хәзерге татар торулыкларын планлаштыруның төп принцибы билгеле бер максатта төзелеш зоналарына аерудан, авылларны торак һәм житештерү өлешләренә бүлүдән гыйбарәт. Шул ук вакытта борынгы авылларның күпчелегендә планлаштыруның тарихи формалары — урамлап-кварталлап, урамлап-радиаль урнашу төрләре һ.б. сакланган. Соңгы дистә елларда РФ терр-ясендә татар авыллары күпкә азая. 2010 ел башына РФдә 4 мең тирәсе татар, татар-башкорт, татар-чуаш, татар-рус һ.б. катнаш авыллар, ш.и. ТР-да — 2 меңнән артык, Башкортстан Респ-касында — 1 мең, Көнбатыш Себердә 0,2 мең чамасы авыл исәпләнә. Татар торулыкларында уртача 300 гә якын кеше, Пенза өлкәсендәге иң зур татар авылы Урта Әләзәндә 10 меңнән артык кеше яши.

Авыл утарының төзелеш рәвешендә этник традиция чагыла. Т. тәрәзәләрнең күбесен кояш ягына каратырга омтылалар. Утарлар, башлыча, 2 өлешкә бүленә: алгы, чиста ишег-



Татар торагы интерьеры (Рәссам З.Ф.Гыймаевның «Әбигә хат килде» картинасы. 1979).



Таза тормышлы крәстиян йорты. 20 йөзнең 1 нче чиреге корылмасы. Арча районы Яңа Кырлай авылы.

алдында торак, саклау урыннары (келәт, амбар, баз, а.х. кораллары өчен лапас һ.б.), терлекчелек корылмалары (сыер, ат, сарык абзарлары һ.б.), җәйге аш-су әзерләү бүлмәсе (Әстерхан һәм Себер Т.ында җәйге учаклар — тындыр, казанных, чувал киң тарала) урнаша; арткы өлешне яшелчә бакчасы, ындыр, әвен-шәше, кибәклек, печәнлек, кайбер очракларда мунча били. Кайбер төбәкләрдә бай крәстияннәрнең утарлары өч өлешкә бүленә, урта өлештә терлекчелек корылмалары урнаша. Бер өлештән торган, торак һәм хуҗалык корылмалары бер түбә астында берләштерелгән Г-рәвешендәге яки йомык төзелештән гыйбарәт утарлар сирәгрәк очрый. Ука бассейнындагы мишәр авылларының үзенчәлеге саклау урыннарының утар тышында урнашуында чагыла (ул корылмалар урамнан һәм күрше утардан колгалы һәм такталы киртә яки читән б-н әйләндерелеп аерылган). Әстерхан Т.ына камыш коймалы, саман яки читән киртәле утарлар, карагашлар өчен калмык торакларына охшаш киез тирмәләр хас.

1930–40 елларга кадәр Т. тупланып яшәгән күп кенә урыннарда торак йортлар планында этник үзенчәлек саклана. Татар авылларының күпчелегендә агач идәнле, сирәк очракларда җир идәнле, ике (кайбер очракларда дүрт) яклы салам яки агач (сирәк кенә — калай) түбә б-н ябылган озынча йортлар төзелгән. Йортларның диварлары түгәрәк бүрәнәләрдән, сирәгрәк очракларда табигый таштан яки кирпечтән корылган. Т.да борынгы традиция буенча нигәләр тоташкан урыннарны балчык б-н сылау, сыланган җирләрне агарту гадәте сакланып килгән.

Т.ның этник традицияләре йортларның тышкы бизәлешендә дә чагыла. Казан артында Казан Т.ының элеккеге корылмалары — бай тормышлы авыл кешеләренең уелган һәм ябыштырылган орнамент, архит.-декоратив детальләр — ордерлы колонкалар, пилястралар, җиңел верандалар, галереялар һ.б. б-н бизәлгән ике һәм өч катлы йортлары сакланган. Казан Т.ының буралы тораклары бизәкләрендә борынгы өч кырлы-уемлы сырлау ысулы уңышлы рәвештә ябыштырылган контурлы, кисүле бизәкләр б-н чиратлаша. Мишәр өйләренең бизәлешенә купшылык хас түгел.

Т.да йортның традицион планы ике һәм өч өлешкә бүленүдән гыйбарәт. Ике яклы йорт өйдән һәм өйалдыннан тора. Өч бүлмәле йортта 2 өй өйалды б-н тоташа. Урманлы р-ннарда өйалды аша келәт б-н тоташкан өйләр, хачсыман планлы тораклар, «түгәрәк» йортлар өстенлек итә. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Идел буе–Урал алды Т.ында ярымподвал рәвешендәге торак яки хуҗалык бүлмәләре булган ике һәм өч катлы йортлар очрый. Эшмәкәрлек яки кәсепчелек эшчәнлеге б-н шөгыльләнгән бай кешеләр авылларда һәм шәһәрләрдә күп бүлмәле, катлаулы планлы йортларда яшәгәннәр.

Өйнең эчке типик планы Т.ның барлык төркемнәре өчен бердәй хас булган. Ишек янында авызы йортның алгы диварына каратылган, чуен казан урнаштырылган һәм казан астында аерым ягу урыны булган мич торган. Өйнең алгы өлешендә түр башы булып, шунда ук *сәке* урнаштырылган. Сәкегә киез яисә җәймә җәелгән, аңа утырып ашаганнар һәм ятып ял иткәннәр, өстенә урын-җир әйберләрен куйганнар. Т. таралып урнашкан төньяк төбәкләрдә, бигрәк тә мишәрләрдә, өй эчендә кыска сәкеләр, өстәлләр урын алган. Шулай ук ишек янындагы почмакка агач кроватьлар да куелган. Йоклау урыннары *чаршау* яки *чыбылдык* б-н бүленгән. Өйнең мич авызы каршындагы өлешендә аш-су әзерләнгән, шунда ук биек булмаган такта өстәл торган, диварга савыт-саба һ.б. өчен капкачсыз-ишексез, ачык шкаф беркетелгән. Татар өйләренең диварлары, бүлемнәре һәм почмаклары гадәттә ачык төсләрдәге тукымалар, тукылган һәм чигелгән сөлгеләр, тастымаллар һәм *намазлыклар* б-н бизәлгән. Ишек өстендә — шәмаилләр, керәшен Т.да алгы почмакта иконалар куелган. Матча буйлап һәм диварларның югары периметры буенча кашага эленгән. Өйнең эчке бизәлеше идәнгә җәелгән өйдә тукылган җәймә, бай өйләренең интерьеры киез келәм б-н тулыландырылган (к. *Торак*).

19 йөздә — 20 йөз башында татар костюмы күлмәктән, киң, иркен итеп тегелгән чалбардан, өске киемнән, баш һәм аяк киеменнән, бизәнү әйберләреннән торган катлаулы комплекстан гыйбарәт булган. Ир-ат һәм хатын-кыз милли киеменең нигезен өйдә тукылган, соңрак — фабрикада эшләнгән тукымадан тегелгән озын күлмәк тәшкил иткән.

Хатын-кыз күлмәкләрен озын җиңле, утыртма якалы итеп тегкәннәр, итәкләрен бала итәкләр б-н, күкрәк өлешен аппликация, күкрәк бизәме (*изү*) б-н бизәгәннәр. Милли киемдә сызыклы-геом. бизәкләр өстенлек итә, әкренләп алар чәчәк-үсемлек бизәкләре б-н алыштырыла. Салып куела торган бизәнү әйберләре хатын-кыз киеменә өс-



Казан татарлары традицион киемнәрдә.



Шәһәр татар хатын-кызлары.
20 йөз башы фоторәсеме.

тәмә күркәмлек бирә: кыйммәтле ташлар, металлардан һәм пыяладан тезелгән муенсалар, *беләзекләр*, *алкалар*, *йөзекләр*, муен-күкрәк (яка чылбыры), күкрәк (изү) һәм чәч толымы бизәмәләре (*чулпы*), көмеш тәңкәле асма бизәкләр. Хатын-кызларның традицион баш киемнәре (*калфак*, кашпау, *өрпәк* һ.б.) урынына 20 йөзнең 1 нче яртысында төсе, сыйфаты һәм бәйләү ысулы төрлелеге б-н аерылып торган яулыклар кулланылышка керә.

Т. күлмәк өстеннән, гадәттә, *камзул* (ул кыска яисә озын җиңле, яки җиңсез, туры яки билләп тегелгән булырга мөмкин) кигәннәр. Хатын-кыз камзуллары бизәкле, ешрак бер төстәге бәрхет тукымадан тегелгән, кырый капламалары һәм аскы өлешләре укалы тасма, мех б-н каймаланган. Ирләр камзул өстеннән зур булмаган шәл якалы озын киң җилән кигәннәр. Елның салкын вакытында тукымадан эшләнгән бишмәтләр, чикмәннәр, кайры туннар киеп йөргәннәр. Ир-атларның көндәлек киеме тизрәк үзгәреш кичерә, руслар киеме тегелешенә якыная.

20 йөзнең 1 нче яртысында, элеккеләре б-н бергә, киемнәрнең яңа төрләре барлыкка килә: җиңел хатын-кыз кофталары, сарафаннар, итәкләр һ.б., ш.у. фабрикада җитештерелгән тукымадан туры һәм билләп тегелгән кыска туннар, пальтолар, плащлар, фуфайкалар һ.б. Татар авылларында аяк киеменең традицион төрләре — киез итекләр, күн *читекләр*, еш кына төсле күннән тегелгән йомшак һәм каты табанлы чүәк-башмаклар, *чабаталар*; баш киемнәре — ярым сфера рәвешендәге *түбәтәйләр* яки киселгән конуссыман кәләпүшләр, конус рәвешендәге колакчынлы мех бүрекләр, ярымсфера яки цилиндр формасындагы катлап тегелгән тукыма (мескен) бүрекләр, кырлары төшеп торган киез эшләпәләр һ.б. (к. *Бүрек*) әле чагыштырмача озак кулланылышта була.

Шәһәрдә яшәүче татар кешеләренең, аеруча җәмгыятьнең югары катлау вәкилләренең киеме Европа модасы йогынтысында үзгәрешләр кичерә. Хәзерге вакытта шәһәрләрдә дә, авылларда да гомумкабул ителгән шәһәрчә киемнәрдән йөриләр. Шуның б-н бергә 20–21 йөзләр чигендә татар халкының милли киемнәрен яңартуга омтылыш көчәя бара. Ул проф. һәм үзешчән сәнгать коллективларында киң кулланыла.

Татар халык мәдәниятенең бер өлешен тәшкил иткән туклану системасы чагыштырмача тотрыклы булып кала. Аш-суның составында, аны әзерләү ысулларында һәм туклану режимы, табын элементлары һ.б. б-н бәйле гадәткә әверелгән кайбер тәртипләрдә төп ризык төрләренең милли асылы саклана. Вакытлар узу б-н Т. ның азык-төлек рационы рус, украин, Урта Азия һәм Көнбатыш Европа кухнясы ашлары хисабына (щи, борщ, варениклар, голубцы, мантый, пылау, яңа өлгергән, тозланган һәм консервланган яшелчәләр, яшелчә һәм ит салатлары, балык ашлары һ.б.) шактый тулылана.

Азык-төлекнең составы бөртеклеләр җитештерү өстенлек иткән игенчелек хас күп тармаклы а.х.ның үзенчәлекләре б-н билгеләнә. Туклануның нигезен икмәк, он һәм ярмадан әзерләнгән азыклар, ит, май, сөт һәм сөт ризыклары тәшкил итә. Арыш һәм бодай икмәген түгәрәк яисә озынча зур ипи савытларында ачы яки чүпрә куеп әчетелгән камырдан пешергәннәр. Чүпрәле яисә төче камырдан көлчә, кабартма, күмәч, белен, коймак, *пәрәмәч*, *өчпочмак*, *бәлеш*, *сумса* ясаганнар. Төче камырдан кайнап торган майда кыздырып борынгыдан ук килгән милли ашлар — *бавырсак*, *кош теле*, юка һ.б.ны әзерләгәннәр. Шулпада пешерелә торган камыр ашлары: токмач, чумар, умач һ.б. бик популяр булган. Элек-электән үк пилмән кулланылган. Т. тары, карабодай, борай, солы, арпа, бодай ярмаларыннан әзерләнгән боткалар ашаганнар; җәй көне балтырган, кузгалак һ.б. үсемлек яфракларыннан аш пешергәннәр. Бәрәңге, кабактан әзерләнгән ризыклар киң кулланылган. Яңа өлгергән, киптерелгән, варенье һәм как рәвешендәге җиләк-җимешләрне куллану Әстерхан Т.ы арасында күбрәк таралган булган. Т.ның башка төркемнәре арасында элегрәк җиләк-җимеш бакчачылыгы булмау урман җиләкләре һәм кыргый үләннәр җыю хисабына хәл ителгән.

Көндәлек азык рационын яңа сауган, кайнатылган һәм әчетелгән сөт (*катык*, сөзмә һ.б.), эремчектән әзерләнгән *корт*, сыр, ш.у. бия сөтеннән эшләнгән әйрән, кымыз кебек



Татар халык ашлары йорты продукциясе.
1970 еллар.



«Өчпочмак һәм пәрәмәч». Рәссам Е.В.Зуев. 1978.
ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

эчемлекләр тәшкил иткән. Чәй эчү аерым популярлык казанган. Элек-электән күпчелек авыл кешеләре чәй урынына мәтрүшкә, бөтнек, сары мәтрүшкә, гөлҗимеш, карлыган, кура җиләге яфраклары һәм җимешләре, юкә чәчәге һ.б. җирле үләннәрне пешереп эчкәннәр.

Элек авыл һәм шәһәр халкының зур күпчелеге ит ашларын бары бәйрәм көннәрендә генә әзерләгән; сыер, сарык, ат итен кулланганнар, салкыннар төшү б-н, кош ите (нигездә, каз, үрдәк) файдаланылган. Бәйрәмнәрдә хәллерәк Т. ат итеннән, ш.у. кош итеннән йорт казылыгы, каклаган (сирәгрәк ысланган) ризыклар (*казылык*, калҗа, ойгыз һ.б.) әзерләгәннәр. Т.да *тутырган тавык* әле һаман да бәйрәм ашы буларак кабул ителә. Итне озаграк саклау өчен (нигездә, каз итен) тозлап һәм киптереп куйганнар.

Хәзерге вакытта көндәлек һәм бәйрәм табыннарында Т. өчен традицион булган ләвәш, бәлеш, көлчә, кош теле, бавырсак, *чәк-чәк*, белен, токмачлы аш, боткалар, пешкән, томалап пешерелгән һәм какланган ит, сөт һәм сөт ризыклары, ш.у. яшелчә ашлары (борщ, щи һ.б.), варениклар, мантый, шашлык, койка, салатлар, компот, квас һ.б. киң кулланыла. Яшелчәчелек һәм бакчачылык бик тиз алга китү сәбәпле, кышка яшелчә һәм җиләк-җимеш әзерләү, кәбестә, кыяр, помидор тозлау, җиләк-җимеш киптерү, яшелчә һәм җиләк-җимешләрне маринадлау һәм консервлау киң кулланылышка керә (к. *Милли аш-су*).

19 йөздә — 20 йөзнең башында татар гаиләсенең кече – ике буынлы (ата-аналар–балалар) һәм киңәйтелгән – өч буынлы төп ике формасы яшәп килә. Т.да туганлык мөнәсәбәтләре бергәлеге фәкать аерым очракларда (мәс., Себер Т.ында туганлык социумнары — тугым рәвешендә) күзәтелә. Т. бергә тупланып яшәгән кайбер төбәкләрдә җир аз булу, җәмәгать тәртипләре, игенчелек өчен уңайсыз булган кишәрлекләр, а.х.нда җитештерүнең түбән дәрәҗәсе, ш.у. үзенчәлекле йомык тормыш рәвеше бергә яшәүче патриархаль гаиләләр сакланып калуга китерә. Акрынлап товар-акча мөнәсәбәтләре йогынтысында зур гаилә коллективларының өлешчә яисә тулы таркалу процесслары көчәя бара.

20 йөз башында Т.ның гаилә көнкүрешендә төп патриархаль традицияләр саклана. Өлкән ир-ат — бабай, ата барлык хуҗалык

эшләрен бүлүче һәм гаилә башлыгы булып торган. Мал-мөлкәт барлык гаилә әгъзаларының уртак милке исәпләнгән. Җенескә һәм яшькә карап, традицион хезмәт бүленеше яшәп килгән. Кече гаиләләрдә, аеруча карт ата-аналар булмаган гаиләләрдә, үзара мөнәсәбәтләр бәйсезрәк була. Татар гаиләсенең эчке төзелеше, тулаем алганда, Россиядә яшәүче күп кенә башка мөселман халыклары гаиләләрендәге яшәү рәвешеннән әллә ни аерылмый (ислам диненең традицион нигезләренә таяна). Т.да хәзерге гаиләләр шәһәрдә һәм авылда – кече, күбесенчә ике буынлы; авыл җирләрендә өч буынлы гаиләләр дә (ир, хатын, балалар, ирнең яки хатынның ата-аналарыннан тора) очрый. Гаилә эчендәге мөнәсәбәтләргә демократияләшү тенденциясе хас. Соңгы унъеллыклардагы социаль-икътисади һәм иҗтимагый-сәяси үзгәртеп корулар гаилә институтының балалар тәрбияләүгә зур игътибар бирү, этник һәм мораль-әхлакый кыйммәтләргә тартылу, тугандаш гаиләләрнең һәм гаиләара кооперациянең бәйләнешләрен киңәйтү б-н бәйле традицион уңай кыйммәтләрен яңартуга булышлык итә. Гаиләнең тормыш итү өчен җитештерүдәге традицион роле арта, аның икътисади функциясе көчәя (к. *Крәстиян (фермер) хуҗалыгы*, *Шәхси ярдәмче хуҗалык*). 20 йөздә социаль һәм милли составы буенча катнаш гаиләләр киң тарала. Әгәр дә элегрәк бер милләт кешеләре арасында гаилә коручылар күбрәк булса, 20 йөзнең соңгы чирегеннән башлап, катнаш никахлар һәм гаиләләр саны кискен арта. Моңа Т.ның таралып урнашуы, катнаш милләт вәкилләре яшәгән торулыклар саны күбәю, халыкларның мәдәни интеграциясе процесслары сәбәпче була. Т. б-н бергә башкортлар яшәгән урыннарда татар-башкорт никахлары югары процент тәшкил итә. Әмма милләтара никахларның өстенлекле өлеше руслар б-н корыла. Милләтара катнаш никахлар һәм гаиләләрнең өлеше арту үзеннән үзе Т.ны этномәдәни руслаштыруның актив факторына әверелә (к. *Гаилә*).

Этник традицияләр озак вакытлар Т.ның гадәткә әверелгән үз-үзеңне тоту культурасында, аерым алганда, халык тормышының аеруча тотрыклы өлешен тәшкил иткән туй йолаларында сакланып килә. Т. бергә тупланып яшәгән урыннарда җирле вариантлар булган очракта, татар туйларына хас төп йола күренешләренең уртаклыгы күзәтелә. Элек йоланың туй алды циклы кодалаудан башланган, аннары, *калым* түләп, кыз ярәшү һәм шәригать кушканча кушылуны беркетеп кую — *никах* йолалары б-н дәвам иткән, соңыннан болар һәммәсе кияү яки кәләш йортында, я булмаса алар йортларында чиратлашып, туй табыннары б-н төгәлләнгән. Казан Т.ында туй табыннары ирләр һәм хатын-кызлар өчен аерым корылган (кайчак аерым урыннарда). Кәләш никахка кергәнгә кадәр *бирнә* (кияүгә һәм аның туганнарына бүләкләр) әзерләгән, туй ашлары (кияү бәлеше, чәк-чәк), башка милли ризыклар пешергән. Йолалар вакыйгага булган көнне катгый тәртип б-н алып барылган. Иң үзәк тантана — туй, ул яшьләрне бүләкләү һәм кунакларны сыйлау б-н бара. Тулаем алганда, туй тантанасының милли үзенчәлеге йолаларның күптөрлелегендә һәм купшылыгында, туйның тормышчан уенчак күңеллелеккә корылуында, кунакларны никахка һәм туйга чакыру тәртибендә, кияү йортын бизәүдә, яшьләр кичәләрендә, аш-су төрлелегендә һәм көчле исерткеч эчемлекләрнең булмавында, туй җырларында, кыз елату, бию йолаларында ачык чагыла. 1930 елларга кадәр Т.ның барлык төркемнәрендә дә туй йолаларында уртаклыклар саклана. 20 йөзнең 2 нче чирегеннән башлап, туйларның «совет моделе» (никахны загста рәсмиләштерү, мөселманча никахны тыю, «кызыл туйлар» һ.б.) кереп урнашу нәтиҗәсендә, туй йолаларын бердәйләштерү күренеше күзәтелә, шулай да аларда кайбер традицион этник элементлар сакланып кала. Хәзерге вакытта авыл, кайчак шәһәр туйларында да, элек урнашып калган күп кенә йолалар башкарыла. Туй алды йолалары циклы шактый кыскартылса да, күп кенә урыннарда кодалау, туй ашлары пешерү һ.б. шундый йолалар камилләштерелгән рәвештә үтәлә. Бирнәгә һәм бүләкләргә зур игътибар бирелә. Акрынлап дини никах ритуалы яңарыш ала (к. *Туй йолалары*).



Татарлар көнкүрешеннән (Рәссам Ф.Х.Якуповның «Килен каршылау» картинасы).

Бала туугa һәм мәет җирләүгә бәйле йолалар Т.ның барлык терр. төркемнәрендә дә охшаш диярлек: аларның нигезендә мөселман гореф-гадәтләре ята. Бала туугa бәйле йолалардагы күп кенә элеккеге гадәтләр (кендек әбисенең баланы таптыруы, яңа туган баланың авызына бал һәм май сөртү һ.б.) юкка чыккан. Ана кеше баласы б-н бала тудыру йортыннан кайткач, Т. тупланып яшәүче күп кенә урыннарда «бәби мунчалары», «бәби чәйләре», мулла һәм якын ир-ат туганнарны чакырып, балага исем кушу һ.б. йолалар башкарыла. Соңгы елларда татар гаиләләренең барысында диярлек ир балаларны *сөннәткә* утырталар (к. *Бала туугa бәйле йолалар*).

Мәет җирләүгә бәйле йолаларда борынгы традицияләр өлешчә саклана: төнге мәет саклау, Коръән сүрәләрен уку һәм анда булганнарга *сәдака* бирү. Мәрхүмне искә алу йолаларын ныгып урнашкан тәртип буенча (җирләгәннән соң өченче, җиденче, кырыгынчы көннәрендә һәм бер елдан соң) Коръән сүрәләрен уку, сәдака тарату һәм исерткеч эчемлекләрсез ритуаль табын кору б-н уздыру кабул ителгән (к. *Мәет җирләү һәм мәрхүмне искә алу йолалары*).


Т.ның иҗтимагый тормышында, күп кенә башка халыклардагы кебек үк календарь бәйрәмнәр һәм йолалар әһәмиятле урын тота. Алар ислам дине кабул ителгәнгә кадәрге гомумтөрки нигездә барлыкка килгән һәм шул ук вакытта кайбер үзенчәлекләре б-н аерылып торган. Казан Т.ында, язгы чәчү башланганчы, Сабан туен бәйрәм иткәннәр. Баштарак аны уздыруның төгәл көне булмаган (бер төбәктәге авылларда билгеле бер чират б-н уздырылган). 1992 елдан башлап, Сабан туе гомуреспуб-ка бәйрәмнәре исемлегенә кертелә, аны үткәрү вакыты хөкүмәт тарафыннан билгеләнә. Казан Т.ының тагын бер милли бәйрәме – Җыен ш.у. чиратлап берничә авылда билгеле бер вакытта (май ахыры–июнь башында) 3–5 көн дәвамында уздырылган. Авылларда суйган казларны бергәләп эш итү — *каз өмәсе* дә бәйрәмчә чарага әверелгән. Т.ның аерым төркемнәрендә җәй айларында яңгыр чакыру өчен коену йолалары үткәрелгән. Себер Т.ы календарь бәйрәмнәрне: әмәл (иран. хәмәл — март) бәйрәмен — Яңа ел башлану бәйрәмен (ритуаль ашлар, мәс., вак крендельләр — тукан пешерү б-н



«Сабан туе». Рәссам Л.Г.Фәттахов. 1957. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.



Бәйрәм киемнәре: 1) шәһәрдә яшәүче таза тормышлы татарлар; 2) татар крәстияннәре.










**Татарлар.** 1. Россия мөселманнары җыены – «Изге Болгар җыены». Болгар ш. 2008; 2. Бөтендөнья татар конгрессы бинасы; 3. ТРның Свердловск өлкәсендәге даими вәкиллеге. Екатеринбург ш.; 4. Россия татар милли-мәдәни автономияләре һәм җәмгыятьләре җитәкчеләре. Казан. 2002; 5. Бөтендөнья татар конгрессы активистлары. 2003; 6. 2 нче Бөтенроссия «Түгәрәк уен» фестивале. Төмән ш. 2009; 7. Әстерхан шәһәрендәге федераль Сабан туенда «Чишмә» халык ансамбле (Волгоград ш.). 2008; 8. Сан-Франциско (АКШ) татар ансамбле. 2008.

уздырылган), кошлар каршылау (карга туе) бәйрәмен (ботка пешереп, балаларны сыйлаганнар), боз озатуны (суга үзләре ясаган курчакларны, көмеш тәңкәләр һ.б. ны ыргытканнар), табигатькә чыгып чәчү башлану көнен (кара бачкар туе) билгеләп үткәннәр. Әстерхан Т. ында мартта ш.у. әмәл бәйрәм ителгән (мәчеттә булып кайтканнан соң, бәйрәм сыйлары б-н уртак табын корылган, ат чабышы, көрәш һ.б. уздырылган), көзен зират бәйрәме (каберләрне карау, аларда гыйбадәт кылу, корбан китерү б-н билгеләп үтү) үткәрелгән.

Календарь бәйрәмнәр б-н бергә Т. тупланып яшәгән барлык урыннарда мөселманнарның дини бәйрәмнәре зурлап уздырылган. Аларның иң әһәмиятлеләре корбан китерү бәйрәменә (*Корбан бәйрәме*), Ураза тәгәлләнүгә (Ураза бәйрәме), Мөхәммәд пәйгамбәр туган көнгә (Мәүлид) багышланган. Бу бәйрәмнәрнең йолалы өлеше иртән мәчеттә ирләр җыелып бергә намаз укудан гыйбарәт булган, өйләрдә туганнар арасында гаилә тантаналары уздырылган. Керәшен Т. христиан бәйрәмнәрен билгеләп үткәннәр. 1992 дән Корбан бәйрәме, Ураза бәйрәме һәм Раштуа (Рождество) ТРның рәсми бәйрәмнәр календарена кертелгән (к. *Мөселман бәйрәмнәре, Православие бәйрәмнәре*). Хәзерге вакытта элеккеге календарь циклының күп кенә традицион элементлары саклана. Татар авылларында һәм шәһәрләрдә язгы чәчү тәгәлләнгәч, печәнгә төшү алдыннан һәр җирдә диярлек Сабан туе бәйрәмнәре уза. 21 йөз башыннан Россия төбәкләре шәһәрләренең берсендә ел саен федераль Сабан туе үткәрелә.

Т. — жанр структурасы һәм муз. чагылышы төрле булган борынгы шигъри мәдәниятkә ия халык (к. *Татар әдәбияты*). Әкиятләр, риваятьләр, әйтемнәр, мәкальләр, ырымнар, бәетләр, дастаннар, мөнәҗәтләр киң тарала (к. *Фольклор*). Җырлар татар шигъри фольклорының аеруча массачыл таралган жанры булып кала (к. *Тарихи җырлар, Кыска җырлар*), аларда тарихи, социаль һәм гаилә-көнкүреш күренешләре хакында бәян ителә (к. *Музыкаль культура*).

Фольклорның кайбер жанрлары хәзерге вакытта да яши (әйтемнәр, мәкальләр, табышмаклар һ.б.). Т. тупланып яшәгән районнарда татар халык лирик җырлары популярлык казана. Алар өлкән буын вәкилләре, үзешчән һәм проф. коллективлар тарафыннан саклана килә.

20 йөз ахырыннан, ТССРның дәүләт суверенлыгы турындагы Декларация кабул ителү (1990), РФдә татар халкының этномәдәни суверенлыгы ныгу нәтиҗәсендә, Т. арасында милли мәдәни традицияләр яңарышы тенденциясе көчәя. Милли тарихка һәм мәдәнияткә карата кызыксыну үсә. РФдә Т. тупланып яшәгән шәһәрләрдә һәм районнарда, ерак һәм якын чит илләрдә татар милли-мәдәни җәмгыятьләре, сәүдә-икътисади вәкиллекләр төзелә, фольклор ансамбльләре, театр студияләре, татар мәдәнияте кичәләре һәм бәйрәмнәре оештырыла, татар телендә газеталар чыгарыла, Т. өчен гимназияләр, мәктәпләр, сыйныфлар һәм якшәмбе мәктәпләре ачыла (к. *Бөтендөнья татар конгрессы корылтайлары, Татарларның милли-мәдәни автономиясе, Татарстан Республикасының вәкиллекләре*).

*Әд.:* Баттал Г. Казан төркиләре. К., 1996; Хаков В.Х. Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе. К., 1997; Дәүләт Н. Русия төркиләренең милли көрәш тарихы (1905–1917). К., 1998; Дәүләтшин Г.М. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. К., 1999; Происхождение Казанских татар. К., 1948; Воробьёв Н.И. Казанские татары. К., 1953; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Мухамедова Р.Г. Татары-мишари: Ист.-этногр. исслед. М., 1972; Хасанов Х.Х. Формирование татарской буржуазной нации. К., 1977; Валеев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Фахрутдинов Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984; Татары // Народы мира: Ист.-этногр. справ. М., 1988; Халиков А.Х. Татарский народ и его предки. К., 1989; шул ук. Кто мы: булгары или татары? К., 1992; Алишев С.Х. Исторические судьбы народов Среднего Поволжья. XVI — начало XIX в. М., 1990; Шарифуллина Ф. Касимовские татары. К., 1991; Кузеев Р.Г. Народы Среднего Поволжья и Южного Урала (Этногенетический взгляд на историю). М., 1992; Томилов Н.А. Этническая история тюркоязычного населения Западно-Сибирской равнины в конце XVI — начале XX в. Новосиб., 1992; Астраханские татары. К., 1993; Валеев Ф.Т.-А. Сибирские татары. К., 1993; Исхаков Д.М. Историческая демография татарского народа (XVIII — начало XX вв.). К., 1993; шул ук. Этнографические группы татар Волго-Уральского региона (принципы выделения, формирование, расселение и демография). К., 1993; шул ук. От средневековых татар к татарам нового времени (этнологический взгляд на историю волго-уральских татар XV-XVII вв.). К., 1998; Татары // Народы России: Энцикл. М., 1994; Газиз Г. История татар. М., 1994; Гришин Я.Я. Польско-литовские татары (Наследники Золотой Орды). К., 1995; Сабирзянов Г.С. Народы Среднего Поволжья и Южного Урала в панораме веков. К., 1995; Хозяйство татар Поволжья и Урала (сер. XIX — нач. XX вв.). К., 1995; Мухамедова Р.Г. Татарская народная одежда. К., 1997; Сагитова Л.В. Этничность в современном Татарстане. К., 1998; Тагиров И.Р. Очерки по истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999; шул ук. История национальной государственности татарского народа. К., 2000; Народный костюм татар Поволжья и Урала. К., 2000; Татары. М., 2001; Рашитов Ф.А. История татарского народа: С древнейших времён до наших дней. Саратов, 2001; Обряды и праздники татар Поволжья и Урала (Годовой цикл. XIX — нач. XX вв.): Ист.-этногр. атлас татарского народа. К., 2001; Урманче Ф. Лиро-эпос татар Среднего Поволжья. К., 2002; Файзрахманов Г.Л. История сибирских татар (с древнейших времён до начала XX века). К., 2002; Этнотерриториальные группы татар Поволжья и Урала и вопросы их формирования: Ист.-этногр. атлас татарского народа. К., 2002; История татар с древнейших времён: В 7 т. К., 2002–15; Закиев М.З. Происхождение тюрков и татар. М., 2003; шул ук. История татарского народа: Этнические корни, формирование и развитие. М., 2008; Этнография татарского народа. К., 2004; Исхаков Д.М., Измайлов И.Л. Этнополитическая история татар (III — середина XVI вв.). К., 2007; Фахрутдинов Р.Г. Золотая Орда и татары. Что в душе у народа. Н.Челны, 1993; Rorlich A.-A. The Volga Tatars: a Profile in National Resilience. Stanford, 1986; Frank J.A. Islamic Historiography and «Bulghar» Identity among the Tatars and Bashkirs of Russia. Leiden-Boston-Keln, 1998; Kemper M. Sufis und Gelehrte in Tatarien und Baschkirien, 1789–1889: der Islamische Diskurs unter russicher Herrschaft. B., 1998.

*Д.М.Исхаков, И.Л.Измайлов.*

**ТАТАРЛА́Р ТУРЫНДА́ РОССИ́Я КАНУННАРЫ́**, югары хакимиятнең 16 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында Россия дәүләтендә яшәгән татар халкының тормышын тәртипкә салучы кануннары һәм күрсәтмәләре җыелмасы. Т.т.Р.к. *Казан ханлыгы* Рус дәүләтенә кушылганнан соң формалаша башлый. 16–17 йөзләрдә, нигездә, Мәскәү патшаларының фәрманнары (грамоталар, боерыклар, күрсәтмәләр) рәвешендә гамәлгә куела. Аеруча мөһим актлар Земство соборы катнашында чыгарыла, аерым кануннар Боярлар думасы б-н берлектә кабул ителә. 18 йөздә, император тарафыннан игълан ителгән исемле фәрманнар б-н беррәттән, татарлар турында кануннарны Югары яшерен совет, Министрлар кабинеты, Сенат, Синод чыгара. 19 йөздә Дәүләт советы, Министрлар кабинеты, 1906 дан соң Дәүләт Думасы кануннар чыгару эшчәнлеге алып бара. Т.т.Р.к. үсешендә төп тенденция татар халкын гомумдәүләт хокук мәйданына кертүдән, аны икътисади, социаль, дини мөнәсәбәтләрдә бердәйләштерүдән гыйбарәт була. Шуның б-н беррәттән канун-фәрманнарның үтәлеше шактый зур дәрәҗәдә дәүләт һәм идарә итүнең агымдагы ихтыяҗлары б-н билгеләнә. 16 йөзнең 2 нче яртысында татарларга багышланган күпсанлы фәрманнар шәхесләргә юнәлтелгән характерда була, Рус дәүләтенә хезмәткә күчкән татар феодаль сыйныфы вәкилләренә бүләк-ташламалар бирүне (күбрәк җир рәвешендә) күздә тота (к. *Йомышлы татарлар*). Канун актларының аз санлы, әмма мөһим төркемен Урта Идел буендагы Рус православие чиркәвенең миссионерлык эшчәнлеген оештыруга кагылышлы фәрманнар тәшкил итә (к. *Иван IV нең Казан архиепископы Гурийга җибәргән күрсәтмәсе, 1555; Патша Фёдор Иванович Фәрманы, 1593*). 17 йөздә кануннар тематикасы киңәя. Җир биләү һәм җирдән файдалануны тәртипкә салучы документлардан тыш, татарларның хәрби хезмәткә һәм сәүдәгә мөнәсәбәтен билгеләүче фәрманнар барлыкка килә. *Кануннар мәҗмугасы* (1649) әлеге чорның мөһим кануннар истәлеге булып тора, анда Россия дәүләтенең күпмилләтле характеры чагыла, татар халкы өчен күп кенә мөһим нигезләмәләр хокукый яктан беркетелә (Урта Идел буенда яшәүче рус булмаган халыкларның җирләрен рус җир биләүчеләренә күчерүне тыю, суд эшләрен башкару процессында Коръән б-н ант итү мөмкинлеген, ислам динен пропагандалаган өчен үлем җәзасына тартуны билгеләү). 17 йөзнең 2 нче яртысында Т.т.Р.к.нда югары хакимиятнең йомышлы татарларның җир һәм милеккә бәйле хокукларын аларның диннәре б-н бәйләү омтылышы чагыла. Аларның православие динендәге крәстияннәре булган утарларын тартып алуга юнәлдерелгән кануннар кабул ителә (тулы күләмдә тормышка ашырылмый). 18 йөз башыннан хокукый мәйданга кертү процессы көчәя, кануннар эзлекле рәвештә татар халкы тормышының яңа өлкәләрен колачлый. Пётр I нең исемле Фәрманнарын (1713 һәм 1715) тормышка ашыру нәтиҗәсендә татар феодаль сыйныфы чынлыкта бетерелә. Йомышлы морзалар һәм православие динен кабул иткән татарлар рус дворяннары сафларын тулыландыралар, ә чукынырга теләмәүчеләрне алпавыт җирләреннән һәм буйсынган кешеләрдән мәхрүм итәләр, 1719–24 еллардагы кануннар аларның дәүләт крәстияннәре катлавына күчешен хокукый яктан формалаштыра, ясаклы татарлар да шул катлауга керә. Моннан тыш Пётр I нең 1718 ел 31 гыйнвар Фәрманы б-н йомышлы морзаларга һәм татарларга Адмиралтейство ихтыяҗлары өчен корабльләр төзүгә яраклы агач материаллары әзерләү һәм чыгару буенча йөкләмә бирелә. Әлеге канун акты Т.т.Р.к. махсус бүлегенең — *лашманнар* турында кануннарның башлангычы була, ул кануннар актив үстерелә һәм, 1817 дә «Лашманнар турында нигезләмә» кабул ителү б-н, тулысынча формалаша. 18 йөздә рус хөкүмәтенең кануннар чыгару сәясәтендә дин мәсьәләсе мөһим урын били. 1720–23 тә рус булмаган халыкларга православие динен кабул итәргә этәргән фәрманнар чыга. Анда яңа чукынганнарның билгеле бер вакытка (гадәттә, 3 елга) акчалата һәм натуралата йөкләмәне (ш.и. рекрутлык) үтәүдән азат ителүе карала. 1730 елларда Урта Идел буенда миссионерлык эшчәнлеге активлашу өчен алшартлар барлыкка килә (1731 дә *Яңа чукындырылганнар конторасы* оештырыла, 1735 тә чукындырылмаган һәм яңа чукындырылган балаларны укыту өчен мәктәпләр ачу турында фәрман чыгарыла). *Император Анна Иоанновна Фәрманы* (1740 ел 11 сент.) 1740–50 елларда *христианлаштыру сәясәте* кампаниясен башлап җибәрә. Татар феодаль аксөякләренә юнәлдерелгән алдагы кампанияләрдән аермалы буларак, ул гомуми характерда була, актив адм., көч һәм икътисади яктан дәүләт катнашы б-н уза, мөселманнарга каршы юнәлдерелгән кануннар сериясе б-н ныгытыла. Бик күп мәчетләрне юкка чыгару, татар халкының матди хәлен начарайту, тулаем төбәкнең чукынган мәҗүсиләренең (марилар,

мордвалар, чуашлар, удмуртлар) салымнарын һәм йөкләмәләрен татарларга йөкләү шуның нәтиҗәсе булып тора. Дини җәберләүләр, салымнар һәм йөкләмәләр арту татарларны Урта Идел буеннан Урал алдына һ.б. төбәкләргә качарга мәҗбүр итә (к. *Татарлар һиҗрәте*), ул җирләрдә *православие миссионерлары* эшчәнлеге нык җәелми. 18 йөзнең өчтән бер өлешендә стихияле һиҗрәт канун нигезендә әзәрлекләнә, ләкин 1734 тә Оренбургка нигез салу турында фәрманга кул куелу б-н, хөкүмәт халыкның Россия дәүләтенең көньяк-көнчыгыш чикләренә күченүен хуплый башлый. Хакимлек итүче *Сенат фәрманы* (1744 ел 8 март) сәүдә эшчәнлеге алып бару өчен 200 татар гаиләсен Казан губернасыннан Оренбург губернасына күчерергә рөхсәт бирә. Алар тарафыннан нигез салынган *Каргалы бистәсе* Россиянең Урта Азия б-н транзит сәүдә үзәгенә әверелә. 1755 тән, *Батырша хәрәкәте* башлану б-н, канун чыгару сәясәтенең юнәлеше либеральләшү ягына күчә. Император *Екатерина II* идарә иткән чорда татар халкы тормышының төрле өлкәләренә кагылышлы мөһим хокукый карарлар кабул ителә. Яңа чукындырылганнар конторасын бетерү турындагы Сенат фәрманы (1764 ел, 6 июнь), Кануннар комиссиясе күрсәтмәсе (1767), Изге Синод фәрманы (1773 ел 17 июнь) дәүләтнең дин ирекен тану сәясәтенә күчешен хокукый яктан формалаштыра. Ислам дин буларак рәсми рәвештә танылa, ләкин православие чиркәвенең өстенлекле дәрәҗәсен яклаучы кануннар нигезендә аның үсеш мөмкинлекләре чикләнә. *Император Екатерина II Фәрманы* (1788 ел 22 сент.) б-н Уфа дини Мөхәммәди канун Җыены (1796 дан — Оренбург Мөхәммәди дини Мәҗлесе, к. *Россия һәм БДБның Европа илләре мөселманнары үзәк диния нәзарәте*) оештыру мөселман руханилары статусының хокукый яктан формалашуының һәм дини җәмгыятьләр б-н идарә итү ин-тлары барлыкка килүнең башлангычы була. 1780 еллардан патша хөкүмәте Казакъстанда һәм Урта Азиядә Россия йогынтысын көчәйтү өчен татар муллаларын файдалана, кануннар кыргыз-кайсак (казакъ) далаларында мәчетләр төзүне хуплый. Бер үк вакытта лашманнар хәрәкәтен җиңеләйтүче, татар халкының эшмәкәрлек активлыгын стимуллаштыручы фәрманнар кабул ителә. Император Екатерина II Фәрманы (1784 ел 22 февр.) б-н татар бәкләренең һәм морзаларының хокуклары Россия дворяннары б-н тигезлиләр. 19 йөздә татарларның хокукый хәләте элеккеге кебек чагыштырмача дәрәҗәдә аларның мөселман динендә булуы б-н билгеләнә. *Николай I* нең идарә итүе кануннар чыгару ягыннан үзенә бер активлыгы б-н билгеләп үтелә, ул вакытта ислам һәм аның тарафдарларына кагылышлы 190 лап рәсми акт басыла (документлар күп юнәлешлелек һәм капма-каршылык б-н характерлана). Кануннарның күбесендә Урта Идел буенда һ.б. төбәкләрдә православие чиркәве позициясен ныгыту максаты күздә тотыла. Николай I миссионерлыкны мөһим дәүләт функциясе буларак карый һәм аңа һәрьяклап булыша. 1842 дә аның Фәрманы б-н Казанда Руханилар академиясе ачыла, яңа чукынганнарга ташламалар бирүче, христианнарга һәм мәҗүсиләргә ислам тәэсирен таратырга комачаулаучы актлар басылып чыга. 1845 тәге Җинаятьләр мәҗмугасында исламга керүгә «котырту» өчен мал-мөлкәткә хокуклардан мәхрүм итү һәм 8 елдан алып 10 елга кадәр каторга хезмәтенә җибәрү рәвешендә җәза бирү карала. Россия дәүләте сәясәтенең православие характерында булуы ш.у. хокук актларында да чагыла, ул мөселманнарга гомумдәүләт стандартлары дәрәҗәсенә күтәрелгән христианнарның яшәү нормаларын көчләп тага. 1830 да һәм 1835 тә православие динендәгеләрнең өйләнешү һәм мәет җирләү буенча билгеләнгән вакыт кысаларын мөселманнарга таратучы фәрманнар кабул ителә. Мондый документлар барлыкка килү татарларга Россия хокук киңлегенә керү процессын катлауландыра, хакимиятнең яңа карарлар кабул итүе алдан ук аларда тискәре караш уята. Николай I заманында мөселман руханилары эшчәнлегенә регламент ясауга зур игътибар бирелә. Ул вакытта Уфада Оренбург Мөхәммәди дини Мәҗлесе, Симферопольдә Таврия Мөхәммәди Идарәсе эшләү принциплары һәм вәкаләтләре билгеләнә, урыннарда мөселман руханиларын сайлау тәртибе законлаштырыла. 1828 дә мәхәллә имамнарына метрика кенәгәсе язуны йөклиләр, 1850 дә аларны тән җәзасыннан һәм рекрутлык йөкләмәсеннән азат итәләр. 1855 тән рухани булырга теләүчеләр өчен яшь цензы гамәлгә кертелә (казый, ахун, мөхтәсиб һәм мөдәррисләр өчен — 25 яшьтән, хатип һәм имамнар өчен — 22 яшьтән, мөәзиннәр өчен — 21 яшьтән). 1829 да һәм 1844 тә Николай I мөселманнарның гыйбадәт корылмаларына регламент билгеләүче «үрнәк» мәчетләр проектын раслый. Россия империясе составына яңа мөселман төбәкләрен кертү, илдәге халык исәбендә мөселманнар өлеше арту хөкүмәтне исламга хөрмәт күрсәтүгә юнәлтелгән карарлар чыгарырга мәҗбүр итә. 1830–40 елларда Идел буе һәм Урал алдының күп кенә шәһәр горнизоннарында, хәрби госпитальләрдә, ш.у. дәүләтнең төрле төбәкләрендәге эре хәрби берләшмәләрдә хәрби муллалар вазифасы кертелә, аларга казнадан хезмәт хакы түли башлыйлар, 1849 елгы фәрман нигезендә мөселман дине кагыйдәләрен белү буенча «түбән дәрәҗәдәгеләр»дән сынау алырга мәҗбүр итәләр. Мөселманнарга тапшырылучы Россия орденнарындагы христиан дине символлары (тәре, изгеләр сыннары һ.б.) империя бөркете б-н алыштырыла, «мөселман динендәге» тоткыннар җомга көнне намаз уку өчен хезмәттән азат ителәләр. 19 йөзнең I яртысында мөселман хокукларының аерым кагыйдәләрен рәсми тану һәм аларны илнең мөселман җәмгыятьләре эчендә гамәли куллану Т.т.Р.к.ндагы аерым үзенчәлек булып тора. Милек, мирас һәм гаилә мөнәсәбәтләрендәге мәсьәләләрне хәл итүдә *шәригать* кануннары б-н эш итү мөмкинлеге бирелә. Вакытлар узу б-н, дәүләт мәхкәмә һ.б. инстанцияләрдә имамнар катнашуын стимуллаштыра башлый, чөнки бу мөселманнар күз алдында хакимиятләр карарларын закон көченә кертә. 1860 елларда Россиядә милли сәясәттә мөһим борылыш була. Патша хөкүмәте дин ирекен тану принцибыннан кире кайта һәм *руслаштыру сәясәте* формасында рус булмаган халыкларның тизләтелгән тел-мәдәниятен бердәйләштерүгә юнәлеш тота. 1870 тә мөселман җәмәгатьләре карамагында булган мәктәпләрдә һәм мәдрәсәләрдә рус теле сыйныфларын ачу турында «кагыйдәләр» басылып чыга. 1874 тә «Төрле исемдәге башкорт, кыргыз һәм татар мәктәпләрен Халык мәгарифе министрлыгы карамагына тапшыру турында» канун чыгарыла, дәүләт шуның нигезендә мөселман уку йортлары өстеннән күзәтчелек итәргә ниятли (мөселманнар тарафыннан ризасызлык булыр дип шикләнгәнлектән, әлеге хокук актлары тормышка ашырылмый). 1870–80 елларда кануннарга мөселманнарга белем бирү һәм мәхкәмә өлкәләрендә хезмәт урыны биләүдә, адвокат эшчәнлеге алып баруда киртә булучы чикләүләр кертелә. 1870 тә Шәһәр нигезләмәсе тарафыннан җирле үзидарә органнарында вәкил булуга ценз кертелү аларның хокукларын чикли (мөселманнар шәһәр идарәсе әгъзалары күләменең өчтән бер өлешен генә тәшкил итә алалар). 1888 һәм 1890 дагы фәрманнар мөселман руханиларыннан рус телен белүне таләп итә торган белем цензы билгели. Әлеге хокукый чикләүләр, башлыча, Россия империясендәге иң алга киткән мөселман халкы булган Идел-Урал татарларына каршы юнәлтелгән була. Татар буржуазиясе вәкилләренә эшмәкәрлек эшчәнлеге б-н шөгыльләнүне һәм Урта Азиядә милек б-н идарә итүне тыю дини мотивлар б-н аңлатыла (1886). 1890 еллардагы кануннар мөселман татарларга коммерция оешмалары, компанияләре һәм ширкәтләре акционерлары булуга каршы киләләр. 20 йөз башына кадәр татарларның хокуклары чикләнә, дәүләт нигезләренә янаган сәяси һәм социаль-икътисади кризис тәэсирендә патша хөкүмәте эчке сәясәттә беркадәр либеральлеккә күчәргә мәҗбүр була. 1904–05 еллардагы канун актлары сериясендә «дини тормышта» мөселманнарны «канунда билгеләнмәгән кысрыклаудан» арындыру буенча чаралар күрелә. 1905 нең 17 апрель Нигезләмәсе татарлар өчен мөһим роль уйный, дини күндәмлек принцибын аңлатуны киңәйтә (христиан динендә көчләп тоту, чукындырылган татарларның яңадан мөселманлыкка кайтуын эзәрлекләү рөхсәт ителми). 1905 нең 17 октябрь Манифесты да төп гражданлык ирекләрен, ш.и. вөҗдан ирекен игълан итә. Әлеге һәм аннан соңгы хокук актлары Россия җәмгыятенең һәм дәүләт хокук системасының яңадан шәхес ирекен яклаучы буржуаз хокуклар принципларына юнәлтелгән тенденцияне чагылдыралар. «Гаскәрләрдә мөселман руханилары штатын раслау турында» фәрман моның бер мисалы булып тора (1908). Ләкин әлеге процесс әзлекле тәгәлләнми. 1909 дан соң хакимият милли сәясәтнең элекке принципларына һәм алымнарына әйләнеп кайта, татар халкын этник, рухи һәм мәдәни үзенчәлегеннән мәхрүм итәргә ом-

тыла. Россия Дәүләт Думасы *Мөселманнар фракциясе* әгъзаларының татарларны милли һәм дини билгеләре буенча кысуны бетерү буенча омтылышлары мөһим нәтиҗәне бирми.

*Әд.:* Ногманов А.И. Татары Среднего Поволжья и Приуралья в российском законодательстве второй половины XVI–XVIII вв. К., 2002; шул ук. Мусульмане Волго-Уральского региона в российском законодательстве XIX в. // Новая волна в изучении этнополитической истории Волго-Уральского региона. Sapporo, 2003; шул ук. Татары Волго-Уральского региона в царствование Николая I: Религиозный фактор в законодательной политике // Вестн. Чуваш. ун-та. Гуманитарные науки. 2006. № 4; Усманова Д.М. Мусульманские представители в российском парламенте. 1906–1916. К., 2005.

*А.И.Ногманов.*

**ТАТАРЛА́Р ҺИҖРӘТЕ́**, татар халкының даими яшәү урыныннан яңа җиргә күчү процессы. Алтын Урда чорында башлана. Әүвәл бу хәрәкәт Алтын Урдадан һәм соңрак татар ханлыкларыннан Литвага, рус кенәзлекләренә күченгән йомышлы татарларның шул җирләрдә төпләнеп калуы рәвешендә бара (к. *Польша-Литва татарлары, Касыйм татарлары*). 16 йөз уртасында татарлар Чыпца елгасы тамагында (*Нократ татарлары*), Иж елгасы бассейнында төпләнәләр. Казан ханлыгының Рус дәүләте тарафыннан яулануы (1552) һәм шуннан соң башланган руслаштыру һәм *христианлаштыру сәясәте* киң колачлы Т.һ.нә, татарларның Урта Идел буеннан Урал төбәгенә, аеруча төньяк-көнбатыш р-ннарына (анда татарларга этник яктан якын башкортлар, нугайлар һ.б. яши) күченүенә китерә. 16–17 йөзләрдә Урта Урал алдында татарлар, башлыча, Сылва-Ирән елгалары арасындагы бассейнда, Тулва елгасы тирәсендә, Уфа һәм Чусовой елгаларының югары агымы буйларында яшиләр. Алар күпләп Уфа өязенә дә күченәләр. Татарлар Уфа шәһәренә нигез салуда катнашалар, 1591–92 елларда алар шәһәрдә яшәүчеләр составында искә алына. 1564 тән башлап, татарлар Арзамас өязендә төпләнә башлый (1629 елгы мәгълүматлар буенча, анда 216 йомышлы татар, бәкләр һәм морзалар яши). Алатырь «шәһәре» янында татарлар 1613 тән башлап күренә башлый, 1629 да Алатырь өязендә 420 йомышлы татар исәпләнә. 1637 дә Кормыш өязендә 162 кеше (йомышлы татарлар һәм тарханнар) була. Татарлар 1661 елгы смета язуында Карсун чик сызыгындагы Тальск, Карсун кальгаларында теркәлгән. 1678–79 еллардагы халык исәбен алу мәгълүматлары буенча, Көнгер өязендә 789 кеше яшәгән, алар 42 татар авылында (Байсино, Усть Турка, Щелканка һ.б. авылларда) язылган. Сембер шәһәрендә татарлар аңа нигез салынган вакыттан яшиләр (1648), 1653–54 тә Сембер өязендә 10 нан артык татар авылы исәпләнә. Касыйм ханлыгы терр-ясеннән Т.һ. көньякка һәм көньяк-көнчыгышка юнәлә, татарлар тарафыннан тарихи Мещера чикләренә янәшә булган җирләр үзләштерелә. 16 йөзнең 2 нче яртысында — 17 йөзнең беренче утыз елларында Темников өязенә татарларның даими урнашуы күзәтелә. 1670–80 елларда булачак Саратов губернасы терр-ясе үзләштерелә. Касыйм һәм Кадом өязләреннән Т.һ. процессы Керенск, Югары һәм Түбән Ломов юнәлешендә тарала. 17 йөз башында Кадом өязендә 20 татар авылы исәпләнә, Шацк һәм Елатьма өязләренең һәрберсе терр-ясендә 6 дан күбрәк авыл була; 17 йөзнең 2 нче яртысында Керенск өязендә 3 татар авылы искә алына. Әлеге терр-яләрне үзләштерүдә Тенишевлар, Маминнар, Акчуриннар, Кудашевлар һ.б. гаиләләр катнаша. 1678 елгы мәгълүматлар буенча, Кадом өязендә — 642, Касыймда — 354, Шацкида — 385, Керенскида 202 морзалар һ.б. татарлар утарлары була.

18 йөзнең 1 нче яртысында христианлаштыру сәясәте көчәю сәбәпле, бигрәк тә Урал алды төбәкләрендә Т.һ. көчәя. 1719–44 тә Урта Иделдән Урал буена 50 меңләп татар күченә (30 мең чамасы — Казан өязеннән, калганнары Касыйм, Кадом, Шацк, Саранск, Керенск, Инсар, Темников һәм Пенза өязләреннән). Күченүчеләрнең күбесе Уфа һәм Оренбург өязләренә юнәлә, аларның зур өлешен ирекле күченүчеләр тәшкил итә. Арада таза тормышлы татарлар да була, алар Оренбургтан ерак түгел *Каргалы бистәсенә* нигез сала, Урта Азия б-н сәүдә итә. 1762 елгы мәгълүматлар буенча, Воронеж губернасында — 23695, Түбән Новгород губернасында — 20182, Оренбург губернасында 87884 татар исәпләнә. 18 йөз ахырында Урал алды төбәгендә 219,2 мең кеше яши, 19 йөз ахырында татарлар саны 1 млн. кешедән артып китә (башлыча, Ык һәм Агыйдел елгалары арасында). 19 йөздә татарлар, җир җитмәү сәбәпле, күченергә мәҗбүр булалар. 19 йөзнең 2 нче яртысындагы реформалар нәтиҗәсендә Т.һ. Идел-Урал төбәгеннән Урта Азиягә һәм Себергә юнәлә (барлыгы 94,3 мең күченүче исәпләнә, шуларның 40,3 меңе Себердә төпләнә). Т.һ. юнәлешләренең берсе — Россиянең сәнәгать-җитештерү тармагы үсеш алган Европа өлеше (Мәскәү яны, Донбасс), Кавказ, Түбән Идел буе. 19 йөз ахырында Казакъстанда һәм Урта Азиядә Идел-Урал төбәгеннән күчеп килгән 53,6 мең татар, Төньяк Кавказда 8 меңгә якын кеше яши. Окт. рев-циясеннән соң һәм гражданнар сугышы елларында сәяси сәбәпләр аркасында татар халкының кайбер вәкилләре Кытайга, Япониягә, Төркиягә күченә. 1920–30 елларда, күмәкләштерү һәм индустрияләштерү чорында Идел буе–Урал алды татарларының бер өлеше Урта Азиягә, Донбасска һәм Россиянең башка төбәкләренә күченә. 1970–80 елларда Көнбатыш Себер һәм Ерак Көнчыгышка, бигрәк тә нефть чыгару төбәкләренә күченүләр дәвам итә (Төмән өлкәсе татарларының саны өч тапкыр арта). Урта Азиядә, Әзәрбайҗанда, Себердә, Украинада (Донбасс) зур татар диаспоралары барлыкка килә. 1990 еллар башыннан татарларның Урта Азиядән, Себердән, Кавказдан кабат Урта Идел һәм Урал буйларына кайтуы күзәтелә. Ш.у.к. *Диаспора, Мөһаҗирләр хәрәкәте.*

**ТАТАРЛАРНЫ́Ң МИЛЛИ́-МӘДӘНИ́ АВТОНО́МИЯСЕ** (ТММА), РФ терр-ясендә татарлар тупланып яшәгән төбәкләрдә оештырыла; Россиядә татар халкының милли-мәдәни үзбилгеләнү һәм ирекле үзоештыру формасы. РФнең 1996 елгы «Милли-мәдәни автономия турында» Законы нигезендә 2005 елга 23 төбәктә ТММА оештырыла: Башкортстан Респ-касында (1998), Коми Респ-касы (1998), Удмурт Респ-касы (2002); Архангельск (1999), Волгоград (1997), Иваново (1999), Кострома (2000), Ленинград (1997), Мәскәү (1999), Новосибирск (2000), Омск (1998), Оренбург (1998), Пермь (1998), Самара (2001), Саратов (1998), Свердловск (1998), Томск (2004), Төмән (1998), Ульянов (1997) өлкәләрендә; Краснодар краенда, Ханты-Манси автономиясе округында (1999); Мәскәүдә (1998), С.-Петербургта (1997). РФнең ТММАләр теркәлгән төбәкләрендә татар милләтеннән булган 3 млн.га якын кеше яши. Түбән Новгород, Чиләбе, Ярославль өлкәләрендә, Красноярск краенда, Ямал-Ненец һәм Ненец автономияле округларында ТММАләр оештыру буенча эш алып барыла. 1998 нең 20 маенда, оештыручылар буларак, С.-Петербург, Свердловск, Саратов һәм Ульянов өлкәләренең ТММАләре штаб-фатиры Казанда урнашкан Федераль ТММАне (ФТММА) нигезлиләр. Оештыру съездында Федераль ТММАнең Уставы раслана, Советы формалаша, ФТММА Фонды булдырыла. ФТММА Бөтендөнья татар конгрессы (БТК) составына керә, төбәкләрдәге һәр ТММА БТКның мөстәкыйль әгъзасы булып тора. Россиянең ФТММА татар халкының үзенчәлеген саклау, аның милли мәдәниятен, мәгарифен, телен үстерү мәсьәләләрен хәл итү өчен оештырыла. Төбәкләрдәге ТММАләрнең эшчәнлеге даирәсенә ш.у. мәдәният үсеше, милли традицияләрне саклау мәсьәләләре керә, татар сыйныфлары һәм мәктәпләре ачу, ТР югары уку йортларында татар яшьләрен укыту юнәлешендә чаралар күрелә. ФТММА рәисләре: И.Р.*Таһиров* (1998–2002), Р.С.*Вәлиев* (2002–07), И.И.Гыйльметдинов (2007 дән).

*Ф.Я.Уразаев.*

**ТАТАРЛАРНЫ́Ң ТАРАЛЫ́П УРНАШУЫ́**, к. *Диаспора.*

**ТАТАРЛАРНЫ́Ң 1748 ЕЛГЫ́ КУЗГАЛЫШЫ́,** яңа чукындырылганнар өчен рекрутлык йөкләмәсен үтәүгә һәм салымнар түләүгә каршылык хәрәкәте. Күтәрелешкә әзерләнү үзәге Казан губернасының Казан өязе Ибрай авылында була. Хәрәкәт Казан өязенең 18 авылын колачлый. Аны оештыручылар — Якуб Мостаев, Измаил Любаев, Рахманкул Арсланов — крәстияннәрне яңа чукындырылганнар өчен салым түләүне туктатырга, салым таләп иткән очракта, фетнә күтәрергә, короллы күтәрелешкә әзерләнергә өндиләр. 1748 елның феврале башында губерна хакимиятләренә ике «яшерен ташлап кителгән хат»тан күтәрелешкә әзерләнү турында мәгълүм була. Хатларның беренчесендә татарларның Кама аръягында Май чабу бәйрәме вакытында баш күтәрүе ихтимал булуы турында хәбәр ителсә, икенчесендә Казан татарларының күтәрелеп чыгарга җыенулары турында әйтелә. Россия империясе Сенаты Казанга бригадир Бардукевичның гомуми җитәкчелегендә Троицк һәм Ревель драгун полкларын, ш.у. Саранск шәһәрен-

нән өч драгун ротасын, Казанның Татар бистәсенә һәм тирә-яктагы авылларга татарларның ниятләрен ачыклау өчен «ышанычлы кешеләр»не җибәрергә, «коткы таратучылар»ны тотып алырга, татар бистәләреннән һәм авылларыннан коралларны, дары һәм кургашны җыеп чыгарга күрсәтмә бирә. Күтәрелешне оештыручылар кулга алына, 18 татар авылына гаскәрләр кертелә. Чаралар күрү нәтиҗәсендә күтәрелеш булмый кала.

*Әд.:* Витевский В.Н. И.И.Неплюев и Оренбургский край в прежнем его составе до 1758 г. К., 1897. Т. 3. *И.Р.Вәлиуллин.*

**ТАТАРЛАРНЫ́Ң 19 ЙӨЗДӘГЕ́ БАШ КҮТӘРҮ́Е́**, патша хөкүмәтенең социаль, дини һәм милли изүенә каршы күтәрелгән халык хәрәкәтләре. 1) Татарларның Халык мәгарифе министрлыгының 1892 елның 10 июльдә кабул ителгән циркулярына каршы 1892–94 тәге хәрәкәте. Циркуляр нигезендә Казан, Мәскәү, Оренбург уку-укыту округлары татар мәктәп-мәдрәсәләрендә рус цензурасы ризалык биргән китапларны гына куллану рөхсәт ителә, кулъязма һәм чит илләрдә басылган китапларны кулланыштан алырга күрсәтмә бирелә; чит илләрдә белем алган руханиларга укыту тыела. Циркуляр басылып чыгу һәм хакимиятләрнең аны тормышка ашыру буенча гамәлләре (китапларны тартып алу өчен урыннарга жандармнар җибәрү һ.б.) татарлар арасында чуалышларга китерә. Авыл җәмәгатьләре каршылык күрсәтәләр, патша хакимияте вәкилләрен кыйныйлар. Татар буржуазиясе һәм руханилары, циркулярны гамәлдән чыгаруны таләп итеп, югары инстанцияләргә үтенечләр тапшыру кампаниясен оештыралар. 1894 тә циркуляр вакытлыча гамәлдән чыгарыла. 2) 1897 гә билгеләнгән Беренче халык санын исәпкә алуга каршы 1896–97 дәге халык кузгалышы. Халык санын исәпкә алу башлангынчы хакимиятләр тарафыннан татар халкына аның максаты, төп бурычлары аңлатыла, татар авылларында брошюралар (татар телендә) таратыла. Татар халкы исәпкә алуны көчләп чукындыруның яңа омтылышы буларак кабул итә. Чукындыру турында имеш-мимешләр таратуда һәм халык санын исәпкә алуга карата тискәре караш формалаштыруда мөселман руханилары актив катнаша. Крәстияннәр халык санын исәпкә алучыларга каршылык күрсәтәләр, хисапчыларны, җирле хакимият вәкилләрен кыйныйлар һәм куалар, хакимиятләргә үтенечләр тапшыралар. Баш күтәрү Урта Идел буендагы татар авылларының төп өлешен колачлый. Казан губернасында каршылык хәрәкәтендә 220 дән артык татар авылы халкы катнаша. 8 өяздә халык санын исәпкә алу хәрби командалар катнашында уздырыла. Хакимиятләр тән җәзасын киң кулланалар. 1897 нең гыйнвары ахырында баш күтәрү бастырыла. Ш.у.к. *Мөһаҗирләр хәрәкәте, Христианлаштыру сәясәте.*

*Әд.:* Загидуллин И.К. Перепись 1897 года и татары Казанской губернии. К., 2000. *И.К.Заһидуллин.*

**ТАТА́РОВА** Гөлсинә Гали кызы (8.11.1944, Арча ш.), социолог, икътисад фән. канд. (1983), социол. фән. д-ры (1998), проф. (1999). Казан ун-тының механика-матем. ф-тын тәмамлаганнан соң (1967), Фәнни авиация техникасы ин-тында программа төзүче инженер булып эшли (Казан). 1967 елдан ВЛКСМның Ленин райкомында 2 нче секретарь. 1969 дан Мәскәүдә: «Оргэнергострой» ин-тында программа төзүче өлкән инженер, 1971 дән РФАнең Социол. ин-тында баш фәнни хезмәткәр. Бер үк вакытта Мәскәү пед. ин-тында укыта (1991–2008), Дәүләт гуманитар фәннәр ун-тының мәгълүматларның матем. модельләштерү һәм анализлау каф. мөдире (1997), Россия халыклар дуслыгы ун-тында (1998) һәм Россия дәүләт гуманитар ун-тында (2004 тән) укыта. 2003 тән «Социология: методология, методы, математические модели» ж-лының баш мөхәррире. Хезмәтләре социол. тикшеренүләр методологиясенә һәм алымнарына, социологиядә матем. алымнар куллануга, социол. мәгълүматларны анализлауның методологик әзлекле тәртибендәге тел һәм логик структураларына карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Типологический анализ в социологии. М., 1993; Методология анализа данных в социологии (введение). М., 1998; Основы типологического анализа в социологических исследованиях. М., 2004.

*Әд.:* Социологи России и СНГ XIX–XX вв.: Биобиблиогр. справ. М., 1999.

**«ТАТА́РСКАЯ БЕДНОТА́»** («Татар ярлылары»), иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты һәм *Республиканың Запас армиясе* сәяси идарәсе органы. 1919 елның 29 сентябреннән 1921 нең 3 мартына кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 430 саны чыга. 1921 нең 27 гыйнварына кадәр «Красный боец» исеме б-н чыга (Республиканың Запас армиясе Революцион Хәрби Советының сәяси бүлеге органы). Армия штабы басмаханәсендә басыла. Мөхәррирләре — Н.Федорович, В.Ворошилин. Газета б-н Н.Городецкий, П.Горский, С.Дәүләтгәрәев, А.Догадов, Н.Иванович, О.Измайлович, В.Именецкий, С.Красновидов, С.Корбут, А.Мясников, А.Певцов, А.Рыжков, Н.Фирсов һ.б. хезмәттәшлек итә. Оборона Советы, Хезмәт һәм Оборона Советы карарлары, Запас армия Революцион Хәрби Советының боерыклары басыла. Төп игътибар Запас армия эшчәнлеген яктыртуга бирелә, сугышка сәләтле Кызыл Армия частьларын әзерләү һәм фронтка җибәрү мөһим бурыч була. «Т.б.»да махсус курслар, мәктәпләр, уку полклары эше, укуда алдынгы курсантлар, хәрби техника төрләре һәм аларны сугышта куллану, кул сугышы алымнары турындагы мәкаләләр урын ала. Сугышчыларны патриотик рухта тәрбияләүгә, сугышта һәм хезмәттә каһарманлык күрсәтергә әзерлек мәсьәләләренә аерым урын бирелә; сугышта каһарманлык күрсәтү мисалларына багышланган күпсанлы хәбәрләр шул максатка хезмәт итә. Армия сәяси бүлегенең интернациональ бүлекчәләре, бүлекнең татар, чуаш, мари, удмурт һәм мордва секцияләре эшчәнлеге тәфсилләп яктыртыла. Запас армия актив катнашкан Казан–Екатеринбург линиясендә тимер юл хәрәкәтен торгызу барышы турындагы материалларга зур урын бирелә. Газетада армиянең тыныч халык арасындагы сәяси эше, Казанның милли-агарту учреждениеләре эшчәнлеге, наданлыкны бетерү, Запас армиянең 1920 елгы *Сәнәкчеләр фетнәсен* бастыруда катнашу тарихы, ТАССР һәм башка Урта Идел буе автономияләренең оешу һәм үсешенең иң мөһим мизгелләре чагылыш таба. 1920–21 еллар ахырында газета төп игътибарын демобилизацияләнгән кызылармиячеләрнең алдагы язмышына юнәлтә, аларны актив рәвештә тыныч иҗади эшкә кушылып китәргә чакыра. 1920 дә – «Т.б.»ның «Пулемёт. Листок юмора и сатиры», «Бюллетень «Красного бойца», 1921 дә «Бюллетень еженедельной газеты «Татарская беднота», «Красная молодёжь» кушымталары чыгарыла. Кәгазь һәм акча җитмәү сәбәпле, газета чыгудан туктый.

*Әд.:* Зиновьев В.Ф. Опыт Коммунистической партии по интернациональному и политическому воспитанию воинов в период Гражданской войны. 1918–1920 гг. (По материалам Запасной армии Республики): Дис. ... К., 1974. *Т.М.Насыйров.*

**«ТАТА́РСКАЯ ПА́СТБИЩНАЯ»**, люцерна сорты. 1996 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында М.Ш.*Лапина*, З.Ф.Насретдинова, О.Л.*Шайтанов* тарафыннан чыгарыла. Үләннең биеклеге 55–80 *см*, чәчәк оешмасы башлы, кузаклары ярым ураксыман. 1000 орлыкның авырлыгы 2–2,2 *г*. Куагы ярым җәелмә рәвешендә. Яз көне бер вакытта үсеп китүе, куаклануының югары булуы, салкынга һәм тапталуга чыдамлыгы б-н аерылып тора. Печән уңышы 1 *га* дан 80 *ц*, орлык уңышы 2,5 *ц*, яфраклануы 55%. Коры матдәдә протеин 10–20%. 2–3 тапкыр чабып алырга мөмкин, беренче чабып алуга кадәр 45–50 көн уза, кузаклары 115–120 көндә өлгерә. Чәчәк ату вакытында азык сыйфатларын озак саклый. Көтүлекләрдә үстерү өчен билгеләнгән. РФнең Селекция казанышлары дәүләт реестрына кертелгән (2000). Урта Идел (ш.и. ТР) һәм Идел-Вятка регионнарында чәчүгә рөхсәт ителгән.

*Әд.:* Каталог научно-технической продукции. К., 2005.

**«ТАТА́РСКАЯ 1»**, көзге арыш сорты. 1989 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында М.Л.*Пономарёва*, С.И.*Пономарёв*, К.Н.Курмангалин, В.Д.Кобылянский тарафыннан чыгарыла. Сорт уртача өлгерешле, вегетация вакыты 316–340 көн. Үсемлекнең биеклеге 100–115 *см*. Башагы призмасыман, уртача озынлыкта, көпшәк, кылчыклары озын, таралучан, сары төстә. Бөртеге уртача эрелектә, соргылт сары, ярым ачык; 1000 орлыкның авырлыгы 27–32 *г*. Сөрлегүгә һәм салкынга чыдамлыгы югары. Ипи пешерү сыйфатлары яхшы. Тамыр череге һәм кар күгәрегә авыруларына бирешми. 1994 тән РФнең 5 регионы: Урта Идел (ш.и. ТР), Урал, Идел-Вятка, Үзәк һәм Төньяк регионнар буенча дәүләт реестрына кертелгән. Уңышы 1 *га* дан 37,5 *ц*.

**«ТАТА́РСКИЕ КРАЯ́ – ТАТА́Р ИЛЕ́»**, гомуммтатар газетасы. Оештыручысы — ТРның «*Татар-информ*» мәгълүмат агентлыгы. 1990–2007 елларда Казанда татар һәм рус телләрендә нәшер ителә. Исеме үзгәрә: 1990 ның октябреннән 1991 нең апреленә кадәр — рус телендә «Татар-информ», 1991 нең маен-

нан — рус телендә «Татар иле» («Татарские края»), 1991 нең декабреннән татар һәм рус телләрендә дөнья күрә. Сынау саны 1990 ның октябрендә чыга, даими рәвештә 1990 ның декабреннән басыла башлый. Газетаның рус һәм татар басмалары бер-берсен кабатламый. Баш мөхәррир — У.Богдалов, 1998 дән — Ш.*Хамматов*; татар һәм рус телләрендәге газеталарның аерым чыгарылышларының мөхәррирләре: Ф.Хәмидуллин, Г.Хәиров, Г.Морат, С.Дәүләтбаев, Р.Гаффар, А.Тәхәвиев, А.Вәлиуллина, М.Әбсәләмова, Н.Галиев һ.б. була. Татар халкының милли яңарыш хәрәкәте күтәрелгән һәм Татарстанда иҗтимагый-сәяси активлык үскән чорда чыга башлый. «Татар-информ» агентлыгының респ-ка турында оператив мәгълүмати материалын күтәрү, татар милләтен рухи берләштерү һәм бергә туплап ныгытуны көчәйтү өчен оештырыла. Газетада Татарстандагы сәяси һәм иҗтимагый процесслар тәфсилләп яктыртыла




«Татарские края – Татар иле» газетасы.

(мәс., 1 нче санда 1990 ның 30 августында кабул ителгән ТССРның дәүләт суверенлыгы турындагы Декларация басыла). ТРның яңа Конституциясе текстлары дөнья күрә, милли фирка һәм хәрәкәтләрнең (ш.и. Татар иҗтимагый үзәгенең сәяси платформасы) программа документлары, ТР Югары мәхкәмә утырышлары һ.б.дан репортаж һәм хисаплар басыла. Татарстандагы сәяси үзгәрешләр, дәүләт һәм җәмгыять реформаларының катлаулы мәсьәләләрен хәл итү юллары яктыртыла. Тулысынча Россия терр-ясендә һәм аннан читтә яшәүче татарларга багышланган беренче басма була. Материалларның күп өлешендә татар диаспорасы тормышы һәм татар милли оешмалары эшчәнлеге яктыртыла. Татарстанның этник төркеме тарихы, халык традицияләре һәм гореф-гадәтләре, этник культура үсеше проблемалары, татар диаспорасы эчендәге бәйләнешләрне киңәйтү турындагы материалларга зур урын бирелә. Россия өлкәләрендәге татар иҗтимагый һәм мәдәни үзәкләренең башлангычлары хуплана, дөньяның төрле почмакларындагы укучыларның күпсанлы хатлары басыла. Газетаның махсус тематик чыгарылышлары дөнья күрә: «Мөселман йолалары һәм гореф-гадәтләре» («Мусульманские обряды и обычаи»), «Мөнәҗәтләр, борынгы җырлар» («Мунаджаты, старинные песни») һ.б.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«ТАТА́РСКИЕ НО́ВОСТИ»** («Татар яңалыклары»), атналык иҗтимагый-сәяси, мәдәни-агарту газетасы. 1993 елның 4 июленнән Мәскәүдә рус һәм татар телләрендә «Папирус» фирмасы (Мәскәү) җитәкчеләре И.Б.Мөслимов һәм Р.Абдуллин башлангычы б-н нәшер ителә. Нашире — «Мифист» ҖЧҖ. Беренче мөхәррире — И.Б.Мөслимов, 2007 дән — Д.З.Аляутдинова. Газета Россия, ш.и. Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсе татарларының милли үзаңы күтәрелү дулкынында туа. Беренче саны хәйриячеләр акчасына Мәскәүдә Сабан туен бәйрәм итүгә багышлап чыгарыла. Башлангыч чорында Россия башкаласындагы татар диаспорасы проблемаларын чагылдыра. 2000 дә федераль газета статусын ала, анда Россия татарларының күпкырлы тормышы яктыртыла башлый. Редакция акрынлап БДБ илләре, Балтыйк буе, Финляндия, АКШ, Германия, Австралия, Төркия һ.б. илләрдәге татар диаспоралары вәкилләре б-н элемтәләр урнаштыра. Татарстан тормышына багышланган материаллар даими басыла, ТРның РФ төбәкләрендәге вәкилләре мәгълүматлары актив файдаланыла. Татар халкының күренекле вәкилләре — сәясәтчеләр, галимнәр, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре турындагы, татар халкының үткәненә һәм хәзерге тормышына багышланган мәкаләләр урын ала; иң яхшы традицияләр һәм гореф-гадәтләр пропагандалана. Эксклюзив материаллар арасында — ТРның беренче Президенты М.Ш.Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшин, Мөфтиләр Шурасы рәисе Р.Гайнетдин, армия генералы М.Ә.Гәрәев, Россия Теннис федерациясе президенты Ш.Ә.Тарпищев, халыкара журналист Ф.М.Сәйфелмөлеков б-н әңгәмәләр.

**«ТАТА́РСКИЙ»**, суган сорты. 1993 елда Кукмара р-ның «Коммунизмга» к-зында Г.Х.Хөснетдинов, Г.Г.Шәмсетдинов, Е.П.Черщенцов тарафыннан чәчүлекләрдән «Алабуга» сортын сайлап алу юлы б-н чыгарыла. Иртә өлгерешле сорт, 78 көндә өлгерә. Суганчасы бик тыгыз, уртача авырлыгы 37,3 *г*, озынча-түгәрәк формада, коры кабыгы сары төстә, сусыл кабыгы ак, тәме бик ачы. Бер оязда 5–6 суганча була, ашлама һәм сугаруны ярата. Нигездә, шәхси ярдәмче хуҗалыкларда үстерелә. 1996 елда чәчәргә рөхсәт ителә, РФнең Селекция казанышлары дәүләт реестрына кертелә, шул ук елны Татарстанда районлаштырылган.

**«ТАТА́РСКИЙ»**, Спас р-ныңдагы ат үрчетү з-ды. 1919 елда Л.В.Молоствовның ат үрчетү з-ды җирлегендә оештырыла. 1921 дә ТАССР Игенчелек халык комис-ты тарафыннан аның өчен 21 юртак бия (ш.и. 6 баш — рус токымлы юртаклар һәм 15 баш Орлов токымлы юртаклар) сатып алына; пр-тие «ТАССР Игенчелек халык комис-тының дәүләт ат үрчетү заводы» исемен ала. 1929 да завод СССРның ат үрчетү тресты составына керә, 1930 да «Авыл хуҗалыгының 57 нче Татарстан ат үрчетү заводы», 1987 дә «Дәүләт нәселле ат заводы» берләшмәсенең «Т.» дәүләт нәселле ат з-ды исемен ала. 1993 нең 24 маеннан 2006 ның 5 июленә кадәр — шушы исемдә. Хуҗалык составына Гөлеш һәм Никольский (үзәк утары) авыллары керә. А.х. файдалануы җирләренең мәйданы 5313 *га*, ш.и. сөрүлек җирләр 3910 *га*. 1931 дән з-д Орлов токымлы юртаклар үрчетү б-н шөгыльләнә. 1993 тә хуҗалыкта 215 баш нәселле ат, ш.и. 55 бия исәпләнә; ел саен 25–30 баш нәселле ат сатыла; 2,8 мең баш мөгезле эре терлек (900 баш сыер) асрала, 88 мең *т* бөртекле ашлык, 2,6 мең *т* сөт җитештерелә. Бөртеклеләрнең уңышы 1 *га* дан 29 *ц* (1992) тәшкил итә. 1999 дан хуҗалык зыянга эшли. 2007 дән аның терр-ясе «Идеал» крәстиян (фермер) хуҗалыгына карый. Заводта «Пилот» (1939 да 1600 *м* дистанциядә чабышта бөтенсоюз рекордчысы), «Кокетливый» (1960 та 2400 *м* да ил рекордчысы), «Күбәләк» (1968 дә «Орлов призы»н ала) айгырлары, «Дарбле» (1970 тә 3200 *м* да «Приз Мира» һәм 2400 *м* да «Маршал Будённый» призы), И-Я Кстати (1972 дә 2400 *м* да бөтенсоюз рекорды) үстерелә. 2006 да эшчәнлеге туктала. «Т.» з-ды үсешенә В.В.Хлюпин зур өлеш кертә (1948–72).

*И.Н.Афанасьев.*


**«ТАТА́РСКИЙ» АГРОХИ́МИЯ ХЕЗМӘТЕ́ ҮЗӘГЕ́**, федераль учреждение. 1964 елда РСФСР А.х. министрлыгының Казан а.х. тәҗрибә станциясе җирлегендә оештырыла, 1976 да — Татарстан респ-касы а.х. химияләштерү станциясе итеп, 1991 дә «Татарский» проект-эзләнү агрохимия хезмәте үзәге итеп үзгәртелә, 2000 нән хәзерге исемдә. Беренче этапта үзәк элеккеге «Әлмәт» агрохимия хезмәте б-н бергә сөрүле җирләрдә һәм башка а.х. файдалану җирләрендә агрохимик тикшеренүләр уздыра, туфракка күпләп анализ ясый. Туфракта хәрәкәтчән фосфор, калий формаларының булуы буенча туфракның ачылыгына караган агрохимик картограммалар төзелә; ашламалар һәм химик мелиорантлар б-н кырда тикшеренүләр уздыра. 1970 кә беренче тапкыр һәрбер а.х. пр-тиесе кырларында туфракның табигый уңдырышлылык дәрәҗәсе билгеләнә, терлек азыгының туклыклылык кыйммәтен анализлау эше җайга салына. 2001 дән үзәктә 6 структур бүлек эшләп килә: туфрак-агрохимик эзләнүләр, химияләштерү чараларын куллануны оештыру, туфракка һәм агрохимикатларга химик-аналитик анализ, үсемлекчелек продукциясенә химик-аналитик анализ, планлаштыру-икътисад, мәгълүмати тәэминат.

Үзәк эшчәнлегенең төп юнәлешләре: туфрак уңдырышлылыгының агрохимик һәм агроэкологик мониторингы, бәя бирү һәм фаразлау, ашламаларга ихтыяҗны билгеләү һәм куллану планын эшләү, ашламаларның микъдарын исәпләү, ачы туфракларны известьләү буенча проект-смета төзү, туфрак һәм үсемлекчелек продукциясенең токсикантлар б-н пычрануы дәрәҗәсенә, әзерләнгән терлек азыгының сыйфатына контроль, электрон карталар һәм агрохимик картограммалар булдыру, игенчелек элементларын га-

мәлгә кертү. Туфракта агрохимик тикшеренүләрнең беренче туры 3725,1 мең *га* да 1965–70 тә уздырыла; 2 нчесе — 1971–79 да, 3 нчесе — 1980–85 тә, 4 нчесе — 1985–90 да, 5 нчесе — 1991–95 тә, 6 нчысы — 1995–2000, 7 нчесе — 2001–05 тә, 2012 гә барлык районнарда да 8 нче тур төгәлләнә. «Т.» а.х.ү.нең җитәкчеләре: Х.З.Зыятдинов (1964–75), В.А.Дубровин (1975–85), Р.Г.Хәбибуллин (1985–90), А.В.Краснов (1990–92), Ш.А.Алиев (1992–2006), А.А.Локманов (2006 дан). «Әлмәт» станциясе җитәкчеләре: В.Н.Мещанов (1964–69), К.Н.Әхмәтов (1969–87), А.В.Ибраһимов (1987 дән).

*С.Ш.Нуриев.*

**«ТАТА́РСКИЙ МИР»** («Татар дөньясы»), атналык гомумроссия рәсемле федераль мәдәни-агарту газетасы. 2002 елның июленнән Мәскәүдә рус телендә нәшер ителә. Оештыручысы һәм нашире — «Ватаным» оешмасы (Мәскәү). Беренче мөхәррире В.Б.Чурбанов була, 2005 тән — Р.С.*Мөхәммәдиев*; редакция советы рәисе — «Ватаным» оешмасы президенты Р.С.*Акчурин*. Татар халкының тарихы, мәдәнияте, әдәбияты һәм сәнгатенә караган, атаклы шәхесләр, татарларның, ш.у. төрки, мөселман халыкларының хәзерге тормышы һәм проблемаларына багышланган, рус халкының тарихы һәм мәдәнияте турындагы




«Татарский мир» газетасы.

материаллар басыла. Шәрекънең бүгенге дөньядагы роле, 21 йөздәге перспективалары, кыйммәтләре, дин, күренекле кешеләр турындагы мәкаләләргә зур урын бирелә. Газета татарлар тарихын дөнья һәм Россия чынбарлыгының үткәне һәм киләчәге контекстында күрсәтергә омтыла. Даими бүлекләре: «Безнең мирас» («Наше наследие»), «Тарих битләре» (Страницы истории»), «Замандашларыбыз язмышы» («Судьбы наших современников»), «Хәтер» («Память») һ.б. Газета б-н танылган галимнәр, язучылар, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклеләре хезмәттәшлек итә.

**«ТАТА́РСКИЙ 6»**, кукуруз гибриды. 1961 елда Татарстан респ-ка тәҗрибә станциясендә Ш.В.*Вәлиев* тарафыннан чыгарыла. Иртә өлгерешле, югары уңышлы. Респ-ка шартларында «Воронежская 76», «Воронежская 80» сортларына караганда 1 *га* дан уңышы 10–15 *ц* га югарырак. Сөрлегүгә чыдам, куыклы кисәү гөмбәсенә — уртача, корылыкка чагыштырмача чыдам, минераль ашламалар ярата. 1964 тә Татарстанда районлаштырыла.

**«ТАТА́РСКОЕ КРА́СНОЕ»**, тары сорты. 1988 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында Л.Г.*Сәгъдиева*, И.А.Щурина, Ф.М.Никитина, Л.С.Павлова тарафыннан чыгарыла. Уртача иртә өлгерешле сорт, вегетация вакыты 72–80 көн. Үсемлекнең биеклеге 80–90 *см*, яхшы куакланган. Себеркәче кысылган, уртача озынлыкта (20–24 *см*), өлгергәндә азрак бөгелә һәм бакыр төсен ала. Бөртеге кызыл, түгәрәк формада, эре; 1000 орлыкның авырлыгы 8–9 *г*. Ярма сорты югары продуктлы, бөртеге һәм ярмасы яхшы технологик һәм куллану үзлекләренә ия, сөрлегүгә һәм некротик меланозга чыдам. 1993 тән РФнең Урта Идел регионында (ш.и. ТРда) районлаштырыла. Уңышы 1 *га* дан 32,7 *ц*.

**«ТАТАРСТА́Н»**, Казандагы басмаханә. 1920 дә конфискацияләнгән «Милләт» басмаханәсенең элеккеге хуҗалары Г.Әлмәтов, Р.Дәминов һәм В.Йосыпов тарафыннан шәрекъ телләрендәге китапларны басу өчен кооператив артель буларак ачыла. Җиһазларның күп өлеше 1919 да Мәскәү, Петроградтан сатып алына, бер өлешен дәүләт учреждениеләре бирә. 1923 тә «Т.»да «американка» тибындагы 1 басмаханә машинасы, 1 яссы басучы, 1 ротация, 4 китап төпләү, 2 кулдан хәреф кою машинасы, 110 потка якын шрифт була; басмаханә 60 эшче хезмәтенә исәпләнә, әмма анда 30 гына кеше эшли. Совет учреждениеләре, кооператив пр-тиеләр, артель, нәшриятлар, кешеләрнең шәхси заказларын үти. Заказчылар арасында — Татарстан Җир эшләре халык комис-ты, Татарстан Финанс халык комис-ты, «Татсоюз», «Госцирк», «Яңа китап» нәшрияты һ.б. Китаплар, бланклар, игъланнар, этикеткалар басыла. Басмаханә 1929 ның ахырына кадәр эшли.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Становление и развитие татарской советской книги (1917–1932). К., 1989. *Г.Г.Габделганиева.*

**ТАТАРСТА́Н**, к. *Татарстан Республикасы.*

**«ТАТАРСТА́Н»**, газета; к. «*Ватаным Татарстан*».

**«ТАТАРСТА́Н»** кунакханәсе, Казанда; архит-ра истәлеге. 1970 елда арх. М.Х.Агишев, инженерлар О.И.Берим, М.Д.Надыйршин проекты буенча төзелә. Бүлмәләре 6-н 14 катлы корпус пландагы вестибюльле, ресторанлы һәм хезмәт биналары урнашкан турыпочмаклы күләм өстендә калкып тора. Казанда каркасы, плитә түшәмәләре һәм тышкы асылма панельләре тимер-бетон конструкцияләрдән корылган беренче биналарның берсе. Башта кунакханә 1050 кешегә исәпләнә. 120 урынлы ресторан, 24 һәм 10 урынлы 2 банкет залы, бильярд бүлмәсе һ.б. бар. Кунакханәнең вестибюль һәм ресторан интерьерлары бизәлеше архитекторлар М.Г.Хәйруллин, Х.Г.Сөнгатуллин, И.Н.Агишева, рәссамнар С.М.Бубеннов, Р.Ә.Килдебәков про-




«Татарстан» кунакханәсе. Архитектор М.Х.Агишев; инженерлар О.И.Берим, М.Д.Надыйршин. 1970.

екты буенча эшләнә. 2004–05 елларда бинага яңа керү үзәге б-н реконструкция ясала.

*Әд.:* Памятники истории и культуры Казани. К., 1982.

**«ТАТАРСТА́Н»**, айлык фәнни-популяр журнал. *Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте* һәм *Татарстан икътисад фәнни-тикшеренү институты* органы. 1928–31 елларда Казанда татар телендә нәшер ителә, барысы 30 дан артык саны чыга. Журналда татар халкы тарихына кагылышлы мәсьәләләр яктыртыла, тарихи чыганаклар һәм документлар басыла; археол., археографик һәм этнографик экспедицияләр




«Татарстан» журналы (1928–31).

нәтиҗәләре турындагы хәбәрләр (Җ.Вәлиди, Н.Ф.Калинин һ.б.), төбәкне өйрәнүгә караган мәкаләләр (Н.Надиев һ.б.) дөнья күрә. Күп кенә материаллар мәдәни төзелеш проблемаларына, татар теле, әдәбияты һәм сәнгате үсешенә (С.Атнагулов, Җ.Вәлиди, Г.Толымбайский һ.б.) багышлана. Икътисади тематикага: бишьеллык план үтәлешенә, сәнәгать пр-тиеләре, колхозлар һәм совхозлар эшенә, а.х. продукциясе җитештерү темпларын яктыртуга зур урын бирелә. Татарстанны гыйльми

өйрәнү җәмгыятенең фәнни тормышы хроникасы системалы рәвештә басылып бара, милли фәнни кадрлар эшчәнлеге турында белешмәләр бирелә. Яңа фәнни әдәбиятка күзәтүләр, монографияләргә һәм фәнни җыентыкларга рецензияләр ясала.

**«ТАТАРСТА́Н»,** айлык рәсемле иҗтимагый-сәяси журнал. 1991 елда «Коммунист Татарии» ж-лы җирлегендә оеша. Оештыручысы һәм нашире — «Татмедиа» ААҖ. Төрле еллардагы баш мөхәррирләре — А.И.*Афанасьев*, Р.Ә.*Мостафин*, Р.Ә.*Фәттахов*, А.С.Сәлимгәрәев, Д.К.Байчурина, А.Д.Тюрин, Т.Н.Вафина. 1990 елларда теоретик һәм күзәтү характерындагы сәяси, социаль-икътисади язмалар, мәдәни, гуманитар өлкәдәге мөһим проблемаларга багышланган мәкаләләр өстенлек итә. 1998 дә, ТРның беренче Президенты М.Ш.Шәймиев «Т.» респ-каның визит карточкасы» булырга тиеш дип белдергәч, журнал рәсемле, иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис басма буларак чыга башлый. Яңартылган вариант респ-ка өчен яңа төр басма була. Аның битләрендә респ-каның иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади, рухи тормышы панорамасы яктыртыла, актуаль мәсьәләләр күтәрелә, аеруча мөһим проблемалар: Россиянең федерализация сәясәте, үзгәреп торган җәмгыятьтә Татарстанның тоткан урыны, сәяси һәм эшлекле элита эшчәнлеге, дәүләт төзелеше мәсьәләләре һ.б. анализлана. Һәр санда мөһим вакыйгаларга экспертлар карашы, хакимият һәм бизнес вәкилләре б-н әңгәмә, сәяси, икътисади һәм иҗтимагый тенденцияләргә анализ ясала. «Т.» респ-ка министрлыкларында һәм ведомстволарында, шәһәр һәм район хакимиятләрендә, эре пр-тиеләрдә, банк структураларында, «Татарстан» авиакомпанияләре очкычларында, Горький тимер юлының фирма поездларында таратыла. Россиянең төрле өлкәләрендәге, БДБ илләрендәге һәм ерак чит илләрдәге татарлар тарафыннан яздырып алына. 2009 да редакция журналның дизайнын һәм структурасын үзгәртә. Мәгариф, мәдәният, фән, диннең торышы, татарстанлыларның көндәлек тормышы турындагы мәкаләләр күбрәк басыла башлый.

*Р.А.Айнетдинов.*




«Татарстан» журналы.

**«ТАТАРСТА́Н»**, сөт юнәлешендәге мөгезле эре терлекнең яңа токымы. 2006 елда Р.Ә.Хәертдинов, М.Г.Әхмәтов, И.Р.Закиров, И.Б.Сәләхов, М.Г.Нургалиев, Н.Ф.Хөсәенов, И.В.Хәйруллин һ.б. тарафыннан китереп чыгарыла. Токымның продуктлылык сыйфатлары: беренче бозаулаган сыерларның тереләтә авырлыгы — 518 *кг*, ике яшьлек үгезләрнең авырлыгы — 623 *кг*; сыерларның 1 нче лактация буенча сөт продуктлылыгы — 5103 *кг* (майлылыгы — 3,98%, аксымлылыгы — 3,29%), барлык лактацияләр буенча уртача сөт продуктлылыгы — 6407 *кг*. Рекордлы сөт продуктлылыгы — 9698 *кг*. «Т.» токымлы сыерларның сөте универсаль — сыр һәм стерилизацияләнгән продуктлар ясау өчен яраклылыгы бертигез. Сыерларның җилене зур, касә рәвешле, сөт бирү тизлеге — 1,71 *кг/мин*. «Т.» токымы күбесенчә Татарстанның төньяк-көнбатыш районнарындагы 9 нәсел заводында, 36 нәсел репродукторында, 121 товар хуҗалыгында үрчетелә. «Т.» токымы Бөтенроссия токымнар реестрына кертелгән (2006).

*Әд.:* З а к и р о в И.Р., Н у р г а л и е в М.Г., Х а е р т д и н о в Р.А. Селекционеры Татарстана — тысячелетию Казани: тип Татарстанской холмогорской породы крупного рогатого скота // Молочное и мясное скотоводство. 2005. № 5; Развитие племенного молочного скотоводства в Татарстане. К., 2006; Генеалогия, племенные качества, ДНК-маркеры продуктивности быков-производителей Татарстанского типа, черно-пестрой и мясных пород скота. К., 2011; Генофонд быков-производителей молочных и мясных пород в Татарстане. К., 2015. *Р.Ә.Хәертдинов.*

**«ТАТАРСТА́Н»**, Балтач р-нындагы а.х. пр-тиесе. 1930 елда «Кызыл яшьләр» (Иске Салавыч а.) к-зы буларак оештырыла; 1954 тә аңа «Кызыл Йолдыз» (Иске Салавыч а.), Ворошилов исем. (Яңа Салавыч а.), К.Маркс исем. (Салавыч Сәрдегәне а.), Молотов исем. (Биктәш а.) к-злар кушыла. 1963 тә — «Кызыл Татарстан» к-зы, 1967 дә — «Социалистик Татарстан» г-тасы исем. колхоз, 1993 тә «Татарстан» к-зы итеп үзгәртелә. 1996 дан а.х. җитештерү кооперативы, 2003 тән ҖЧҖ, 2006 дан ҖЧҖ а.х. пр-тиесе. Үзәк утары — Иске Салавыч а., 477 хуҗалык, 1749 кеше яши, ш.и. а.х. җитештерүендә 229 кеше эшли (2013). Төп тармаклары — бөртекле ашлык, бәрәңге җитештерү, ит-сөт терлекчелеге. 2013 тә а.х. файдалануы җирләренең мәйданы 4298 *га*, ш.и. сөрүлек җирләр 3657 *га*, хуҗалыкта 2367 баш мөгезле эре терлек (ш.и. 650 сыер), 3001 баш дуңгыз асрала. Шул ук елны 3662 *т* бөртекле ашлык, 2269 *т* бәрәңге, 4477 *т* сөт, 636 *т* ит җитештерелә; бөртекле культураларның уңышы — 40,8 *ц*, бәрәңге 174,5 *ц* тәшкил итә. Хуҗалык 26,7 млн. сум табыш ала. Табышлылык дәрәҗәсе — 49,4%. Хуҗалык а.х. продукциясе җитештерүдә югары күрсәткечләргә ирешкәне өчен күп тапкырлар КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКларының Кызыл байраклары (1979, 1980, 1981, 1984, 1986, 1987, 1988); СССР ВДНХсы дипломнары (1980, 1985, 1987) б-н бүләкләнә. 1981 дә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. Дәүләт бүләкләренә, ш.и. Соц. Хезмәт Герое исеменә — 1 кеше, ТАССРның атказ. автотранспорт хезмәткәре — 1, ТАССРның атказ. агрономы — 5, ТАССРның атказ. механизаторы — 4, РСФСРның — 1, ТАССР, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре — 5, ТАССРның атказ. икътисадчысы — 1, ТАССРның атказ. мелиораторы — 1, ТАССРның атказ. төзүчесе исеменә 1 кеше лаек була; Ленин ордены 1 кешегә, Окт. Рев-циясе — 2, Хезмәт Кызыл Байрагы — 9, «Почёт билгесе» — 7, 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны ордены — 1 кешегә; СССР ВДНХсы медальләре 12 кешегә, ш.и. алтын — 10, көмеш — 1, бронза медаль 1 кешегә бирелә.

Хуҗалык үсешенә Х.Г.*Галимуллин* (1971–96), Р.Р.Нотфуллин (1996–2012), А.Р.Нотфуллин (2012 дән) зур өлеш кертә.

*И.Н.Афанасьев.*

**«ТАТАРСТА́Н»**, Буа р-нындагы а.х. пр-тиесе. 1930 елда Сталин исем. к-з буларак оештырыла. 1950 елда, Фрунзе исем. к-з б-н берләштерелеп, «Т.» исемен ала. 1993 тән — а.х. кооперативлары ассоциациясе, 2003 тән «Нива» ҖЧҖ составында (2005 тән «Вамин-Татарстан» АҖдә). Хуҗалык составына Карлы, Яңа Суыксу һәм Иске Суыксу (үзәк утары) авыллары керә, 758 хуҗалык, 2322 кеше яши, ш.и. 403 кеше а.х. җитештерүендә эшли (2000). Төп тармаклары — бөртекле ашлык, шикәр чөгендере, сөт, ит җитештерү. А.х. файдалануы җирләренең мәйданы 5770 *га*, сөрүлек җирләр 5510 *га*. Хуҗалыкта 1692 баш мөгезле эре терлек (ш.и. 510 баш сыер), 3270 баш дуңгыз асрала (2009). Бөртекле культураларның уңышы 1981–85 тә 1 *га* дан уртача 25 *ц*, 1992–93 тә — 40,3 *ц*, 2000 дә — 52,1 *ц*, шикәр чөгендере шул ук елларда 1 *га* дан 212 *ц*, 175 *ц* һәм 292 *ц*. Хуҗалык җитештерүдәге югары күрсәткечләре өчен Ленин ордены (1967); КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКларының Мактау грамоталары һәм күчмә Кызыл байрагы; СССР ВДНХсы дипломнары (1967, 1977, 1979, 1981, 1983–84) б-н бүләкләнә. 1969 да колхозга «Югары культуралы игенчелек хуҗалыгы» дигән исем бирелә. Хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә һәм мактаулы исемнәргә лаек була, ш.и. РСФСРның атказ. вет. табибе — 1, ТАССРның атказ. агрономы — 2, ТАССРның атказ. механизаторы исеме — 3 кешегә; Ленин ордены — 1 кешегә, Окт. рев-циясе — 2, Хезмәт Кызыл Байрагы — 5, «Почёт билгесе» — 11, 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны ордены — 2 кешегә; медальләр — 22 кешегә, ш.и. СССР ВДНХсы медальләре: көмеш — 2, бронза медаль 9 кешегә бирелә.

Хуҗалык үсешенә К.Ф.Әбелханов (1931–54), Н.С.*Сабирҗанов* (1959–88), Н.С.Җамалетдинов (1988–2003) зур өлеш кертә.

*Әд.:* С а б и р з я н о в Н.С., Е в д о к и м о в З.К., Г а и т о в М.Я. Колхоз «Татарстан»: экономика на подъёме. К., 1984.

**«ТАТАРСТА́Н 2»**, терлек азыгы борчак сорты. 1985 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында Т.Г.*Евдокимова*, А.Н.*Фадеева*, Г.А.Баранова, А.Н.Зеленов, Н.А.Лобанов, Г.С.Титенко тарафыннан чыгарыла. Иртә өлгерешле сорт, вегетация чоры 68–75 көн. Сабагы 75–110 *см* озынлыкта, сөрлегүчән. Яфраклары 2–3 парлы йомыркасыман формада. Кузагы җиңелчә бөгелгән, җимеш бирә тор-

ган буыннарда 1–2 шәрләп урнашканнар. Кузагында 6–9 орлык, ачык сары төстә, түгәрәк, коелучан, орлык өлешләре кызгылт төстә. 1000 орлыкның авырлыгы 140–170 *г*, пешү вакыты югары, составында 22–24% протеин бар. 1989 елда РФнең Урта Идел, Үзәк һәм Төньяк-Көнбатыш регионнарында бөртекле ашлык һәм бөртекле печән өчен районлаштырыла. Яшел массасының уңышы 1 *га* дан 250–270 *ц*. Зур булмаган мәйданнарда үстерелә.

*Әд.:* Каталог научно-технической продукции. К., 2005.

**«ТАТАРСТА́Н АВТОНО́МИЯЛЕ СОВЕ́Т СОЦИАЛИ́СТИК РЕСПУ́БЛИКАСЫ ТУРЫНДА́» ДЕКРЕ́Т**. 1920 елның 27 маенда БҮБК рәисе М.И.Калинин, РСФСР ХКС рәисе В.И.Ленин, БҮБК секретаре А.С.Енукидзе тарафыннан имзалана. Әлеге декретка нигезләнеп, РСФСР составында Татарстан Автономияле Совет Социалистик Респ-касы оештырыла. Аның составына Казан губернасыннан — Казан, Лаеш, Мамадыш, Зөя, Чистай, Тәтеш, Спас (Жедяевка һәм Йорткүл волостьларын исәпкә алмаганда) өязләре, Алабуга өязеннән Чиркәс һәм Салагыш волостьлары, Краснококшайск өязеннән Күлле Киме һәм Кышлау волостьлары; Уфа губернасыннан — Минзәлә өязе; Самара губернасыннан — Азнакай, Александровский, Әбүкәй, Әлмәт, Баулы, Богоявленский, Варварино, Югары Карамалы, Каратай, Кузайкино, Ивановка, Мәсгут, Микулин, Мордва Афонькәсе, Мордва Ивановкасы, Мордва Кармалкасы, Түбән Чергелинский, Яңа Писмән, Салих, Спас, Спиридоновка, Эстәрлетамак, Сумароково, Тымытык, Урсалы волостьлары һәм Бөгелмә өязеннән Чәкән волосте, Вятка губернасыннан — Кошки, Нолинский, Арбор, Яңгул, Сәрдебаш, Түбән Чыты волостьлары һәм Малмыж өязеннән Шода волосте; Сембер губернасыннан — Сөендек һәм Олы Тархан волостьлары һәм Сембер өязеннән Зур Чынлы волосте; Буа өязеннән Иске Суыксу, Янтуган, Шыгырдан, Яңа Кәкерле, Чүпрәле, Мөчәли, Борындык, Ырынгы, Тимбай, Уба һәм Городище волостьлары кертелә. Декрет буенча респ-када дәүләт хакимиятен Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның җирле советлары, ТАССРның ҮБК һәм ХКС гамәлгә ашыра. Эчке эшләр, юстиция, мәгариф, сәламәтлек саклау, социаль тәэминат, җир эшләре (үзидарәле һәм ТАССР ҮБК каршында турыдан-туры җаваплылар), азык-төлек, финанс, эшче-крәстиян инспекциясе халык комис-тлары, ш.у. ХКСның хезмәт һәм юл хәрәкәтен оештыру бүлекләре, почта һәм телеграф идарәсе (турыдан-туры РСФСР халык комис-тларына буйсыналар, аларның күрсәтмәләрен үтиләр) булдырыла. Респ-када хәрби эшләр б-н округ хәрби комис-тына буйсынган Татарстан хәрби комис-ты идарә итә; контррев-ция, спекуляция, аяк чалугa каршы көрәш б-н Бөтенроссия Гадәттән тыш комиссия шөгыльләнә. Тышкы эшләр һәм тышкы сәүдә, финанс һәм техника мәсьәләләре РСФСР үзәк органнары карамагында кала. *Татарстан АССР советларының беренче (оештыру) съезды* чакырылганчы, хакимият тулаем *Вакытлы революцион комитетка* тапшырыла. Респ-ка чикләрен билгеләү мәсьәләсен хәл итү өчен комиссия төзелә.

Чыг.: Образование Татарской АССР: Сб. док. и материалов. К., 1963; Декреты Советской власти. М.,1976. Т.8.

*Әд.:* К л и м о в И.М. Образование и развитие Татарской АССР (1920–1926). К., 1960; Х а ф и з о в Ш.Ш. Образование Татарской АССР. К., 1960; С а й д а ш е в а М.А. И нет счастливее судьбы: В.И.Ленин и социалистическое преобразование Татарии. К., 1987; Т а г и р о в И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999.

*Е.Б.Долгов, Р.В.Шәйдуллин.*

**«ТАТАРСТА́Н АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́»**, айлык а.х. журналы. ТАССР А.х. министрлыгы органы. Казанда 1921–54 елларда татар телендә, 1954–62 дә татар һәм рус телләрендә нәшер ителә. Айга ике тапкыр, 1938 дән ай саен басыла. Исеме үзгәрә: 1921 дән «Игенче», 1930 дан «Күмәк хуҗалык», 1932–33 тән һәм 1935 тән «Колхоз бригадиры», 1934 тән «Югары уңышка», 1949 ның сентябреннән «Колхоз бригадасы», 1954 тән «Т.а.х.», 1954 нең апреленнән «Сельское хозяйство Татарии». Төрле еллардагы мөхәррирләре – Д.Ханзафаров, Г.Г.*Кушаев*, Н.Мансуров, Г.С.Кәбиров, Г.З.*Галиев*, Ш.Рәмзи, И.Үзбәков һ.б. Басманың максаты аграр фәннәр казанышларын пропагандалау, иң яхшы колхозлар, МТС, фермалар, бригадаларның алдынгы тәҗрибәсен гомумиләштерү була. Мәкаләләрдә респ-кадагы а.х. торышы, төрле елларда иген уңмауның сәбәпләре анализлана. Бакчачылык, яшелчәчелек, умартачылык буенча киңәшләр, укучыларның сорауларына җаваплар, а.х. эшләре календарьлары, яңа китапларга күзәтүләр басыла; аларны әзерләүгә әйдәп баручы агрономнар һәм ветеринарлар җәлеп ителә. 1922–23 тә кушымта сыйфатында «Авыл хуҗалыгы сәхифәсе» г-тасы чыгарыла.

*З.З.Гыйләҗев.*

**ТАТАРСТА́Н АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ ИНСТИТУТЫ́**, Р о с с и я  а в ы л  х у җ а л ы г ы  ф ә н н ә р е  а к а д е м и я с е н е ң  ф ә н н и - т и к ш е р е н ү  и н с т и т у т ы (ТатНИИСХ), 1969 елда СССР МС карары б-н *Татарстан республика авыл хуҗалыгы тәҗрибә станциясе* җирлегендә булдырыла. 1987 дә институт «Орлыкчылык» ФҖБ итеп үзгәртелә (1990–2000 дә «Татарстан кырые» ФҖБ), 2000 нән ТатНИИСХ. Институт структурасында 5 фәнни үзәк эшли: селекция-орлыкчылык (көзге арыш, язгы бодай селекциясе бүлекләре; көзге тритикале, көзге бодай, бөртекле-кузаклы культуралар, карабодай, җимеш культуралары селекциясе лаб-яләре; рапс селекциясе секторы), заманча технологияләр (агрохимия, адаптив технологияләр бүлекләре; үсемлекләрне саклау, терлек азыгы җитештерү лаб-яләре; кукуруз секторы; а.х. җитештерүен механикалаштыру төркеме), аналитик тикшеренүләр, бәрәңге биотехнологиясе (бәрәңге селекциясе, биотехнологияләр лаб-яләре), терлекчелек фәнни-тикшеренү үзәге (фәнни эшләрне гамәлгә кертү, сәнәгать терлекчелеге лаб-яләре). Эшләүчеләр саны – 330 кеше, ш.и. 100 дән артык фәнни хезмәткәр (8 фән д-ры һәм 33 фән канд.). Тикшеренүләрнең төп юнәлешләре – игенчелек, үсемлекчелек, зоотехния, механикалаштыру. Институт ТРда ашлык җитештерү процессын фәнни тәэмин итүне гамәлгә ашыра (бөртекле культураларның сортларын, үсемлекләрнең туклану шартларын яхшырту, чәчүлекләрне корткычлардан, авырулардан һәм чүп үләннәрдән саклау), басу культураларын үстерүнең ресурс саклау технологияләре буенча, яңа буын туфрак эшкәртү техникасын булдыру буенча тикшеренүләр; геннарның гамәли кыйммәтләрен һәм сөт терлекчелегендәге аномалияләрне билгеләү буенча тикшеренүләр уздыра. ТатНИИСХта а.х. культураларының 98 сорты чыгарыла, шуларның 73 енә авторлык таныклыгы алына. РФ Дәүләт реестрына ин-тның 57 сорты керә, ш.и. карабодай (10), тары (7), борчак, көзге арыш һәм бодай (4), язгы бодай, арпа, люцерна (3 әр), чия (8), слива (7), алмагач һәм кура җиләге (2 шәр). Т.а.х.и. ТР хуҗалыкларына үз селекциясенең а.х. культуралары орлыкларын (2008 дә 1500 *т*), җиләк-җимеш һәм декоратив культуралар үсентеләрен (2008 дә 3 мең данә), терлекләр өчен азык өстәмәләрен (тәүлеккә 25 *т*) һәм аларны куллану технологияләрен сата. Институт җирлегендә бәрәңгенең халыкара сыйфат стандартларына туры килүче сәламәтләндерелгән бүлбеләрен җитештерү (елына 800–1000 *т*) җайга салынган. Институтның фәнни-тикшеренү эшләре РСФСР (1990), ТР (1999) Дәүләт бүләкләренә лаек була, РФ Хөкүмәте бүләге (2001) — блок-модульле, нигездә, туфрак эшкәртү техникасы комплексын эшләгән һәм гамәлгә керткән өчен (Н.К.Мәҗитов); СССР МС бүләге (1987), РФ Дәүләт бүләге (1994) карабодайның югары сыйфатлы сортларын чыгарган өчен (И.И.*Петелина*, Ф.З.*Кадырова*) бирелә. ТР Дәүләт бүләге — көзге бодайның салкынга, кышка чыдам сортларын чыгарган өчен (1994, Э.Ф.*Ионов*), рапс җитештерү, эшкәртү һәм кулланунын фәнни нигезләнгән технологиясен эшләгән өчен (1997, Р.Г.*Гәрәев*, Ш.К.*Шакиров*, А.В.*Якимов*), агроландшафтлы адаптив игенчелек системасын үзләштергән һәм теоретик нигезләрен эшләгән өчен (1999, А.П.*Пухачёв*, Е.И.*Захарова*), фәнни нигезләнгән орлыкчылык системасы нигезендә көзге арышның югары продуктлы сортларын эшләгән һәм тиз арада җитештерүгә керткән өчен (2001, М.Л.*Пономарёва*, С.Н.*Пономарёв*), ТРда терлек азыгы системасын эшләгән һәм гамәлгә керткән өчен (2004, М.М.*Маликов*, Ф.С.*Гыйбадуллина*, О.Л.*Шайтанов*, Х.З.*Кәримов*), ТРда бөртекле ашлык җитештерүдә ресурс саклау технологияләрен эшләгән өчен (2006, Р.С.*Шакиров*, Г.И.*Шакиров*, А.Н.*Фадеева*) бирелә. Халыкара һәм бөтенроссия күргәзмәләре бүләкләре: 15 алтын, 4 көмеш, 2 бронза медаль. 2004 тә Т.а.х.и.нда 4 белгечлек буенча аспирантура ачыла: а.х.н механикалаштыру чаралары һәм технологияләре, селекция һәм орлыкчылык, үсемлекчелек, а.х. терлекләрен ашату һәм терлек

азыгы технологиясе. 1999 дан «Татарстан кыры» исемле фәнни-җитештерү ж-лы чыга.

Т.а.х.и. җитәкчеләре: Ү.Г.*Биктимеров* (1969–71), Ф.Х.*Минушев* (1971–83), Ф.К.Мусин (1983–86), Х.Х.Исмәгыйлев (1986), Г.Д.Аверьянов (1987), Л.П.*Зарипова* (1988–95), Р.Г.*Гәрәев* (1996–2004), Т.Г.*Һадиев* (2004–06), М.Ш.Таһиров (2006 дан).

*Әд.:* Татарскому научно-исследовательскому институту сельского хозяйства — 50 лет. К., 1971; Гареев Р.Г. Татарскому научно-исследовательскому институту сельского хозяйства «Нива Татарстана» — 80 лет // Нива Татарстана. 2000. № 3; Хадеев Т.Г. Татарскому НИИСХ — 85 // Нива Татарстана. 2005. № 3.

**ТАТАРСТА́Н АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ ҺӘМ КРЕДИ́Т КООПЕРА́ЦИЯЛӘРЕ БЕРЛЕГЕ́** (Татсельскредсоюз). 1927 елның гыйнварында Казанда *Идел-Кама төбәге авыл хуҗалыгы, кредит һәм вак кәсепчелек кооперациясе берлеге* җирлегендә оештырыла. Бүлекләре: тәэминат, а.х., әзерләү-сату, ашлык, сәүдә, колхоз, дәүләт контрактациясе һ.б. Максаты – а.х. һәм кредит кооперативларының эшләрен оештыру, җитештерү кооперациясе учреждениеләренә һәм аерым крәстиян хуҗалыкларына аграр җитештерү культурасын камилләштерүдә финанс-кредит һәм техник ярдәм итү. 1928 нең июнендә ТАССР а.х. кооперациясенең тәэминат-кредит берлеге дип үзгәртелә. 1929 ның июнендә шул җирлектә Татарстан өлкә ашлык җитештерү берлеге барлыкка килә.

**ТАТАРСТА́Н АГА́Ч КИСҮ́ ҺӘМ ЭШКӘРТҮ́ КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́ КООПЕРА́ЦИЯЛӘРЕ БЕРЛЕГЕ́** (Татлеспромсоюз). 1932 елның маенда Казанда оештырыла. Төп максаты – артельләрнең хуҗалык һәм финанс эшчәнлегенә җитәкчелек итү. 1953 нең маенда берлеккә ТАССРның инвалид кәсепчеләр берлеге, Чистай өлкәсенең агач эшләнмәләр кәсепчелеге, Казан һәм Чистай өлкәләре инвалид кәсепчеләр берлекләре кушыла. Урман кисү, агач чыгару һәм агачтан көнкүреш кирәк-ярагы җитештерү б-н шөгыльләнүче кооперациясе артельләрен берләштерә. *Татарстан кәсепчелек кооперативлары Советына* буйсына. 1956 ның маенда, йорт җиһазлары (мебель) җитештерү кәсепчелеге кооперативлары берлеге (Татмебельпромсоюз) б-н кушылып, Респ-ка урман хуҗалыгы, агач эшкәртү һәм йорт җиһазлары җитештерү кәсепчелеге кооперативлары берлеге дип үзгәртелә.

**ТАТАРСТА́Н АЗЫ́К-ТӨЛЕ́К ҖИТЕШТЕРҮ́ КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́ БЕРЛЕГЕ́** (Татпищепромсоюз). 1947 елның маенда Казанда оештырыла. 17 артельне берләштерә. Максаты – азык-төлек җитештерү б-н шөгыльләнүче артельләрнең хуҗалык һәм финанс эшчәнлегенә җитәкчелек итү. *Татарстан кәсепчелек кооперативлары советына* буйсына. 1956 ның апрелендә эшчәнлеге туктатыла.

**ТАТАРСТА́Н АРХИТЕКТУ́РАСЫ**. ТР терр-ясендәге архит-ра тарихы шартлы рәвештә 7 төп чорга: борынгы (10 йөзгә кадәр), Болгар (10 йөз — 13 йөзнең 1 нче яртысы), Алтын Урда (13 йөзнең 2 нче яртысы — 15 йөзнең 1 нче яртысы), Казан ханлыгы (15 йөзнең 2 нче яртысы — 16 йөз уртасы), рус-Россия (16 йөз уртасы — 20 йөзнең 1 нче чиреге), совет (1920 еллар башы — 1980 еллар ахыры) һәм хәзерге (1990 еллар башыннан) чорларга бүленә. Борынгы чорда ныгытылган һәм ныгытылмаган торулыклар барлыкка килә. Әлеге чорга караган ныгытылган торулыклар 2 төрле шәһәрлек хасил итә: гадәти торулык һәм сугыш куркынычы янаган очрак өчен янәшә төзелгән торулык. Ике төрнең дә чокыр һәм туфрак өеме б-н әйләндерелгән ныгытмасы, ә кайвакыт туфрак өеме өстендә башы очланган бүрәнәләрдән коймa, эченә балчык тутырылган ике рәтле бүрәнә конструкцияле диварлар була (1 нче меңьеллык).

Торулыклар, гадәттә, елга ярларының киртләч калкулыклы борыннарында, ә кайвакыт эченә агач буралар салып калдырылган ясалма калкулыклар өю юлы б-н тигез урыннарда да урнаша. Борынгы дәвер тораклары — уртасына учак урнашкан, җир өсте өлеше шалашсыман ярымбалчык өйләр, кыек түбәле бүрәнә, кирәч-бүрәнә, саман конструкцияле кирәч-текмә йортлар, ш.у. терлек асрап көн күрүчеләр яшәгән тирмәләр һәм чатырлар. Башка корылмалардан ш.у. өстенә тәңре-таш балбаллар урнаштырылган ясалма өемнәр рәвешендәге мәҗүси гыйбадәт кылу урыннары, түбәсендәге таш плитәләргә кеше сурәте ясалган төрле зурлыктагы курганнар булуы да мәгълүм. Гарәп сәяхәтчеләре Ибне Фазлан, Ибне Рустә, әл-Гарнати мәгълүматлары буенча (10–13 йөзләр), болгар халкының күпчелек өлеше елның җылы вакытында тирмәләрдә яки чатырларда яшәгән, салкыннар җиткәч, агач йортларга күченгән. Таштан ш.у. гыйбадәт йортлары һәм җәмәгать бипалары төзелгән. Аларның иң борынгылары Болгар чорына карый. Ныгытма коймалары б-н 4 өлешкә: үзәк ныгытма, эчке шәһәр, тышкы шәһәр һәм бистәләргә бүленгән Биләр шәһәрлеге археол. комплексында Җамигъ мәчет, төрбәләр, кәрвансарайлар, таштан һәм кирпечтән төзелгән мунча, торак калдыклары табыла. Алабуга шәһәрлегендә ныгытма-мәчет нигезләре сакланып калган (к. *«Алабуга шәһәрлеге»* манарасы). Стиле буенча ул Якын һәм Урта Көнчыгыш мөселман илләре архит-расы истәлекләренә якын тора, ләкин кыек агач түбә, тамбур (чолан) һ.б. кебек җирле табигый-климатик шартлар б-н бәйләнгән кайбер үзенчәлекле сыйфатларга да ия. Алтын Урда чорында Болгар шәһәрләре архит-расы алгарыш кичерә. Аларда яңа таш монументаль биналар барлыкка килә. Болгар шәһәрлегендә аерым архит-ра истәлекләре, кайбер биналарның хәрабәләре сакланып калган: *Болгар җамигъ мәчете, Кече манара, Көнчыгыш төрбә* һәм *Төньяк төрбә, Кара пулат, Ак пулат, Хан төрбәләре,* Кәрвансарай һ.б. Стильләре шәрекъ архит-расының сәлҗүкләр юнәлешенә якын тора, ләкин, аермалы буларак, аларга үзенчәлекле конструктив элементлар (кыек агач түбә, тамбур (чолан) өлешләренең булуы һ.б.) һәм характерлы бизәкләр хас.

Казан ханлыгы чоры архит-расы агачтан һәм таштан салынган саклану корылмалары, шәһәр һәм авылларда киң таралган агач һәм өлешчә чатыр-тирмә тораклар, шәһәрләргә ислам рухы биргән таш монументаль сарай, гыйбадәт кылу һәм җәмәгать биналары б-н билгеләнә. 10–11 йөзләр чигендә үк сәүдә һәм саклану пункты җирлегендә барлыкка килгән Казан шәһәре 15 йөзнең 40 нчы елларында Казан ханлыгының башкаласына әверелә. Казан терр-ясендә Хан пулатлары, Хан мәчете, *Нургали мәчете, Ханнар төрбәсе* урнашкан таш кирмән диварлар һәм манаралардан торган ныгытма булганлыгы мәгълүм. Шәһәрдә ш.у. Отыч мәчете, *Даир мунчасы* һ.б. таш корылмалар булган. Алар архит-ра формалары б-н Болгар, Алтын Урда, төрек (к. *Госманлы архитектура стиле*) һәм Италиянең элгәрге Ренессанс архит-ра мәктәпләренә якын тора. Соңгысы шул чорда дөньякүләм танылу ала һәм итальян архитекторлары, Рус дәүләтен, Казан һәм Кырым ханлыкларын да кертеп, күп кенә илләргә чакыру ала башлыйлар. Рус-Россия дәверендә Казан ханлыгының монументаль архит-ра традицияләре өзелә. Традицион татар архит-расы үсеше, нигездә, авыл җирлегендә, өлешчә шәһәр төзелешләрендә дәвам итә. Татар кирмән шәһәрләре җимерелә. Алар урынында посадлар б-н әйләндереп алынган рус кальгалары барлыкка килә (к. *Шәһәр төзелеше Татарстанда, Казан Кремле, Казан посады*). Корылмаларның күпчелеге агачтан була. Казанда һәм башка калаларда калган татар халкы шәһәр читендәге аерым урыннарга күчеп утыра (к. *Татар бистәләре, Иске Татар бистәсе*). Бу чорда татар җирләренә күченеп килгән руслар тарафыннан Псков, Мәскәү, Владимир һ.б. архит-ра мәктәпләре традицияләрендә монументаль таш корылмалар төзелә. Архит-ра-шәһәр төзелеше культурасының үзгәрүе яңа төр корылмалар барлыкка китерә. Христиан дине корылмалары — чиркәүләр (к. *Православие чиркәүләре*) һәм *монастырьлар* калкып чыга. Патша наместнигы сарае, приказлар йорты, таможня һ.б. булган Казан Кремле комплексы яңадан кушылган терр-яләрнең хакимият үзәгенә әверелә. Казан посады һәм аны әйләндереп алган бистәләрнең билгеле бер эзгә салынмаган, радиаль-боҗра рәвешендә планлаштырылган структурасы формалаша. 17 йөзнең 2 нче яртысыннан төбәк архит-расында бизәкле кирпеч диварлар, төсле бизәкләр һ.б. б-н аерылып торган гомуми рус стилендәге «кирпечле бизәк» юнәлеше үсеш ала. Бу юнәлеш *Михляев йорты, Әфган-Мөхәммәт Солтан тәкиясе* (Касыйм ш.) һ.б. архит-расында чагылыш таба. 17 йөз ахырыннан рус бизәкле кирпеч архит-расы ордерлы формалар б-н байый башлый.

18 йөз башына кальгаларның диварлары шәһәрләр үсешен тоткарлаучы факторга әверелә. 1730–50 елларда төбәктәге күпчелек шәһәрләрнең, ш.и. Казанның да, посадларындагы урта гасырлардан калган кальга диварлары сүтелә. Бистәләр шәһәр корылмалары б-н кушыла. Россиянең барлык терр-ясендәге шәһәрләрне яңадан планлаштыру һәм аларның төзелешен билгеле бер тәртипкә китерү уңаеннан, Казан (1768), ан-

нары төбәкнең башка шәһәрләре өчен регуляр генплан эшләнә. Шул вакыттан алып, шәһәрләрдәге төзелешләр, нигездә, проф. архитекторлар әзерләгән «үрнәк» план буенча тормышка ашырыла. Казанда регуляр планны эшкә ашыру б-н беренче проф. арх. В.И.Кафтырев җитәкчелек итә (1768 дән). 18 йөз ахырында Казан губерна идарәсендә биналар төзү һәм ремонтлау эшләре планнарын һәм сметаларын карап тикшерү, губернадагы торак пунктларда алып барыла торган төзелешләргә җитәкчелек итү б-н шөгыльләнүче төзелеш бүлеге оештырыла. Анда губерна архитекторлары Ф.Е.Емельянов, Я.М.Шелковников, А.К.Шмидт эшли. 18 йөз башында «кирпечле бизәк»кә алмашка рус *бароккосы* килә. 18 йөзнең 2 нче яртысында татар дини архит-расының барокко стиле һәм традицион урта гасыр күләмле-планлаштыру формаларында кирпеч мәчетләр салына башлый (к. *Казан мәчетләре, Мәчет, Манара*). 18 йөз ахырында Казан губернасы архит-расында барокко стилен — *классицизм*, 19 йөз башында *ампир* алыштыра.

1830 еллар ахырыннан корылмаларның төрләре дә арта. Уку йортлары, хастаханәләр, хәрби хастаханәләр, кабулханәләр, төрмә учреждениеләре, сәүдә йортлары комплексы һ.б. төрле биналар барлыкка килә. Классицизм һәм ампир стилендә төзелгән корылмалар арасыннан Казанда — *Университет шәһәрчеген, Гостиный дворны, Иске Таш мәчет* һәм *Галиев мәчетен, Төрмә кальгасын*, Алабугада *Никольский чиркәвен, Покров чиркәвен, Спас соборын*, Чистайда *Никольский соборын* һ.б.ны күрсәтергә мөмкин.

Авыл төзелешләре халык архит-расы үрнәгендә үсә (к. *Рус халык архитектурасы, Татар халык архитектурасы*). Шәһәр архит-расы йогынтысында классицизм үрнәкләре халык архит-расына да үтеп керә һәм анда үзенчәлекләр формалашуга этәрә. Агач архит-ра истәлекләреннән *Бакиров Вәлиулла йорты, Гатаулла бай йорты, Әсән-Елга мәчете* һ.б. сакланып калган. 1833 тә Россия империясе Эчке эшләр министрлыгының Юллар һәм җәмәгать биналары баш идарәсе карамагында Казан губернасының төзелеш комиссиясе оештырыла. Ул җәмәгать биналары төзү б-н шөгыльләнә, корылма планнарын һәм төзелеш эшләренең сметаларын раслый, корылмаларны исәпкә ала һәм аларга тиешле бәя бирә. 1849 да эшчәнлеге туктатыла. Шул ук елда юллар һәм юл корылмалары төзү, дәүләт учреждениеләре, рухани идарәләргә һәм шәхси затларга биналар төзергә җир бүлеп бирү б-н шөгыльләнүче Казан губерна төзелеш һәм юл комиссиясе оештырыла. 1865 тә вазифаларын Казан губернасы идарәсенең Төзелеш бүлегенә һәм юл төзелеше буенча земство карамагындагы учреждениеләргә тапшырганнан соң гамәлдән чыгарыла. Губерна һәм шәһәр архитекторлары ин-ты формалаша. Бу чорда арх. П.Г.*Пятницкий*, М.П.*Коринфский*, Ф.И.*Петонди* һ.б. эшли. 19 йөзнең 2 нче яртысында Казанда 20 дән артык архитектор эшли. Шулардан иң танылганнары: П.Е.*Аникин*, А.К.*Ломан*, П.Т.*Жуковский*, И.П.*Бессонов*, А.И.*Песке*, П.И.*Романов*, П.В.*Тихомиров*, В.К.*Бечко-Друзин*. 19 йөз уртасыннан 20 йөз башларына кадәр Т.а. – Россиядәге капитализм чорының стиль юнәлешләре: *эклектика*, төрле үзгәрешләр һәм агымнарны стильләштерү; 20 йөз башларыннан *модерн* формаларында үсә. Алар арасында җирле рус һәм татар буржуазиясенең яшәү мохитләренә милли-мәдәни рух алып керү омтылышы б-н бәйле *романтизм* стиле аерылып тора. Яңа типтагы җәмәгать биналары барлыкка килә: *пассаж*, вокзаллар (к. *Казан тимер юл вокзалы*), театрлар (*«Алафузов театры»*), махсус уку йортлары (*гимназияләр, Родионованың затлы нәсел кыз балалар институты, Казан сынлы сәнгать мәктәбе, мәдрәсә, Казан руханилар академиясе* һ.б.), күргәзмә биналары (к. *Казан халыкара күргәзмәсе*), банклар, кунакханәләр, мед. учреждениеләре (*Казан хәрби госпитале, Казан университетының яңа клиникалары, Психиатрия клиникасы бинасы*), клуб биналары (к. *Сәүдәгәрләр җыены бинасы, Дворяннар җыены бинасы*). Шәһәрләрдә табыш йортлары, шәхси йортлар, башка конфессия гыйбадәтханәләре (к. *Санкт-Катарина кирхасы, Синагога, Покров иске дин тарафдарлары чиркәве*) төзелә. Сәнәгать архит-расы үсеш ала (к. *Крестовниковлар заводы биналары, Александров И.В. варисларының сыра һәм сосла кайнату заводы комплексы*).

19 йөз ахыры — 20 йөзләр башында Казан губернасы архит-расы үсешенә арх. Л.К.*Хрщонович*, Ф.Р.*Амлонг*, Г.Б.*Руш*, К.Л.*Мюфке*, Ф.Н.*Малиновский*, С.В.Бечко-Друзин һ.б. зур өлеш кертә. 1920–30 елларда конструктивизм стилендәге биналар аерылып тора (к. *Матбугат йорты*). Архитекторлар Ф.П.Гаврилов, С.С.Пэн әлеге стиль вәкилләреннән була. 1930 елның 2 нче яртысы — 50 еллар ахырында совет *неоклассицизмы* өстенлек итә (к. *Татар опера һәм балет театры*). Казанда әлеге стиль вәкилләре — архитекторлар И.Г.Гайнетдинов, И.А.Вәлиев, П.А.Саначин, Г.И.Солдатов һ.б. 1950 еллар ахыры — 80 еллар ахыры, нигездә, типлаштырылган проектлар буенча алып барылучы барлык төр биналар һәм корылмалар төзелешен индустрияләштерү: сәнәгать комплексларының үсешен тәэмин итү, чит ил архит-расының алдынгы алымнарын актив үзләштерү, тарихи формалашкан шәһәрләрдәге иске корылмаларны реконструкцияләү, җирле архит-ра мирасы һәм монументаль-бизәлеш сәнгатенең традицион формаларын исәпкә алып, яңа биналар төзү (к. *Татар академия театры*), тикшеренүләр, архит-ра-археол. истәлекләрен реставрацияләү һәм югалган йөзен фәнни реконструкцияләү (к. *Реставрация* (архит-ра), *Архитектура белеме, Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы, Биләр шәһәрлеге, Казан Кремле, Зөя*) һәм хәзерге Т.а.нда милли-төбәк үзенчәлекләрен чагылдыруның тарихи-теоретик нигезләрен эшләү вакыты була (И.Г.Вәлиев, С.С.Айдаров, П.С.Саначин һ.б.ның хезмәтләре).

1990 еллардан Т.а. офислар, банклар, сәүдә йортлары төзү хисабына шәһәр үзәген реконструкцияләү һәм төзекләндерү, индивидуаль һәм типлаштырылган проектлар буенча уңайлы йортлар салу; искергән гыйбадәт йортларының югалган функцияләрен тергезү һәм яңа дини корылмалар төзү (к. *Әлмәт мөселман дини мәгърифәт үзәге*, Чаллыдагы *«Тәүбә», «Әбүзәр», «Ихлас»*, Алабуга Җамигъ мәчете, Казандагы *«Рамазан»*, «Хозәйфә ибне әл-Ямәни», Менделеевтагы *«Таң»* мәчетләре, *Түбән Кама җамигъ мәчете* һ.б.); әһәмиятле җәмәгать биналарын төзергә чит ил фирмаларын җәлеп итү, нәтиҗәләрәк төзелеш материалларын һәм эстетик чараларны да кулланып, чит ил архит-ра-төзелеш практикасының алдынгы тәҗрибәсен үзләштерү; төбәкләрдәге үзенчәлекле архитектур чишелешләрне, Т.а.ның тарихи үсешендәге барлык чорларга хас традицион формаларны иҗади фикерләү кебек үзенчәлекләр б-н сыйфатлана (ш.у.к. *Архитектура бизәге*).

*Әд.:* История Татарской АССР. К., 1950. Т. 1; С м и р н о в А.П. Волжские болгары // Тр. Гос. ист. музея. М., 1951. Вып. 19; О с т р о у м о в В.П., Ч у м а к о в В.В. Свияжск. История планировки и застройки. К., 1971; О с т р о у м о в В.П. Казань. К., 1978; А й д а р о в С.С. Архитектурное наследие Казани. К., 1978; ш у л у к. Общее прогрессивное и локальное своеобразие в архитектурной школе Татарстана // Материалы Междунар. науч.-метод. и практ. конф. по архитектуре и дизайну. К., 1999; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; А й д а р о в С.С., Х а к и м о в А.Х., Ю с у п о в Н.З. Память поколений: науч.-попул. очерки о памятниках истории и культуры Татарии. К., 1980; А й д а р о в а - В о л к о в а Г.Н. Архитектурная культура Среднего Поволжья XVI–XIX вв. К., 1997; Х а л и т о в Н.Х. Очерки по архитектуре ханской Казани. Гипотезы. Факты. Размышления. К., 1999.


*С.С.Айдаров.*

**ТАТАРСТА́Н АССР АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ ПРОДУ́КТЛАРЫН ҖИТЕШТЕРҮ́ ҺӘМ ХӘЗЕРЛӘҮЛӘ́Р МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ ҺӘМ ХӘЗЕРЛӘҮЛӘ́Р МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР АЗЫ́К-ТӨЛЕ́К СӘНӘГАТЕ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**. Тарихы 1919 елның 27 гыйнварында Казан губерна ХКС каршында оештырылган, 1920 нең 28 сентябреннән ТАССР ХКС карамагындагы азык-төлек сәнәгате бүлегеннән башлана. Бүлек ТАССР ХКСның 1922 ел 6 гыйнвар боерыгы б-н ТАССРның Азык-төлек сәнәгате берләштерелгән ф-калары һәм з-длары («Татпищетрест») итеп үзгәртелә. ТАССР ХКСның 1930 ел 4 декабрь карары б-н исеме ТАССР Дәүләт азык-төлек һәм спирт сәнәгате берләштерелгән ф-калары һәм з-длары идарәсе («Татсельпромтрест») дип алыштырыла. ТАССР ҮБК һәм ХКСның 1931 ел 4 гыйнвар карары б-н — ТАССР Тәэминат халык комис-тының (1934 нең августыннан — ТАССР Җирле сәнәгать халык комис-тының) азык-төлек сәнәгате секторы


































**Татарстан архитектурасы** мәкаләсенә. 1. Көнчыгыш төрбә. Болгар шәһәре. 14 йөзнең 30 еллары; 2. Кара Пулат. Болгар шәһәре. 14 йөз уртасы; 3. Алабуга шәһәре янындагы «Шайтан каласы» манарасы. 12 йөз (?); 4. Успение ирләр монастыре. Зөя утравы. 16–19 йөзләр; 5. Казан Кремле. 16–21 йөзләр; 6. Петропавел соборы. Казан. 1724–26; 7. Мәрҗани мәчете. Казан. 1766–70; 8. Казан ун-тының төп корпусы. Архитекторы П.Г.Пятницкий. 1822–25; 9. Шәһәр музее. Казан. Архитекторы И.Н.Колмаков. 1895 (хәзер ТР Милли музее); 10. Никола соборы. Чистай шәһәре. Архитекторы П.Г.Пятницкий. 1838; 11. Печән базары мәчете. Казан. Архитекторы А.К.Ломан. 1845–49.































12. Казан хәрби округы командующие йорты. Казан. Архитекторы Ф.Р.Амлонг. 1906; 13. Ушкова йорты. Казан. Архитекторы К.Л.Мюфке. 1904–07 (хәзер ТР Милли китапханәсе); 14. Торак йорт. Казан. Архитекторы В.А.Дубровин. 1940 еллар; 15. «Победа» кинотеатры бинасы. Казан. Архитекторы М.К.Игъламов. 1958; 16. Казан ун-тының физика ф-ты корпусы. Архитекторлары О.А.Кашинцева, В.П.Бондаренко. 1977; 17. «Казан» милли мәдәният үзәге. Архитекторлары А.Т.Полянский, Ю.М.Минаев, инженер В.И.Райцын, 1988; 18. Җамигъ мәчет. Түбән Кама шәһәре. Архитекторлары Р.И.Мануев, В.Г.Ханов. 1989–96; 19. «Ихлас» мәчете. Чаллы шәһәре. Архитекторы В.А.Манукян. 1999; 20. Әмирхан һәм Ямашев проспектлары чаты. Казан; 21. Болгар шәһәрендәге Ак мәчет комплексы. Архитекторы С.П.Шакиров. 2012.

(1933 тән — идарәсе), ТАССР ХКСның 1937 ел 5 февраль карары б-н — ТАССР ХКС каршындагы Азык-төлек сәнәгате идарәсе, ТАССР ҮБКның 1937 ел 26 февраль һәм 26 март карарлары б-н — ТАССР Азык-төлек сәнәгате халык комис-ты, ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы б-н — ТАССР А.-т.с.м., ТАССР ЮС Президиумының 1953 ел 30 апрель карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1953 ел 30 март Указы б-н ТАССР Җиңел һәм азык-төлек сәнәгате министрлыгы, ТАССР ЮС Президиумының 1953 ел 29 октябрь карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1953 ел 12 ноябрь Указы б-н — ТАССР Азык-төлек товарлары сәнәгате министрлыгы, ТАССР ЮС Президиумының 1966 ел 8 гыйнвар карары һәм ЮС Президиумының 1966 ел 12 гыйнвар Указы б-н ТАССР А.-т.с.м. итеп үзгәртелә. Министрлык азык-төлек җитештерү сәнәгатенең җиләк-җимеш-яшелчә, балык, макарон, кондитер әйберләре, май, крахмал-патока, он, икмәк, тәмәке, шикәр, ликёр-аракы, алкогольсез эчемлекләр җитештерү, сыра кайнату, парфюмерия-косметика тармаклары б-н җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра һәм респ-кага буйсынулы, турыдан-туры үзенә караган пр-тиеләр б-н идарә итә. Аның составына адм.-хуҗалык, планлаштыру-икътисад, җитештерү-техник, финанс, кадрлар бүлекләре, бухгалтерия, үзәк лаб. керә. Элек аның карамагында 20 пәп, 1950–80 елларда 30 лап пр-тие була. ТАССР ҮБКна (1938 гә кадәр), ТАССР МСна (1946 га кадәр — ХКСна) һәм РСФСРның шул ук исемдәге Министрлыгына (1946 га кадәр — Халык комис-тына) буйсына. ТАССР ЮС Президиумының 1985 ел 12 декабрь Указы б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары ТАССР Агросәнәгать ком-тына тапшырыла.

Халык комиссарлары һәм министрлар: В.Ф.Анисимов (1937), П.М.Андриянов (1938 нең гыйн.–апр.), Г.Ш.Шаһимәрданов (1938 нең апр.–мае), Е.Я.Матвеев (1938 нең июнь–июле), Н.Х.Латыйпов (1938 нең июле – 1942 нең гыйн.), Г.Г.Измайлова (1942 нең гыйн.–окт.), П.Я.Ватажников (1943–51), В.В.Варламов (1951–53), И.А.Әбдерәфыйков (1953–59), Н.Г.Гайфетдинов (1959–60), У.З.Закиров (1960–63), В.И.Матвеев (1963–68), И.З.Фәтхуллин (1968–73), И.Е.Городнянский (1973–1985 нең гыйн.), В.К.Чаплыгин (1985 нең гыйн.–дек.).

Ш.у.к. *Азык-төлек җитештерү сәнәгате.*

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР АЗЫ́К-ТӨЛЕ́К СӘНӘГАТЕ́ ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**, к. *Татарстан АССР Азык-төлек сәнәгате министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР АЗЫ́К-ТӨЛЕ́К ТОВАРЛАРЫ́ СӘНӘГАТЕ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан АССР Азык-төлек сәнәгате министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР АЗЫ́К-ТӨЛЕ́К ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**. Тарихы 1915 елның маенда оештырылган Казан губерна азык-төлек ком-тыннан башлана. Ком-т Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна советы башкарма ком-тының 1918 ел 21 май карары, Бөтенроссия ҮБК һәм ХКСның 1918 ел 27 май Декреты б-н губерна башкарма ком-тының азык-төлек бүлеге итеп үзгәртелә. Эшче, крәстиян, кызылармияче һәм казак депутатлары советлары 5 нче Бөтенроссия съездының 1918 ел 10 июль карары нигезендә исеме кабат Казан губерна азык-төлек ком-ты дип алыштырыла, Бөтенроссия ҮБК һәм РСФСР ХКСның 1920 ел 27 май Декреты, ТАССР ҮБКның 1920 ел 28 сентябрь карары б-н ТАССР А.-т.х.к. итеп үзгәртелә. Азык-төлек продуктлары һәм көндәлек куллану товарлары хәзерләү, бүлү, алар б-н Кызыл Армияне һәм халыкны тәэмин итүне гамәлгә ашыра. Хәзерләүләр (хәзерләүләрне оештыру, чимал хәзерләү, ит-балык хәзерләү, йомырка-кош ите хәзерләү, печән, савытлар-әрҗәләр хәзерләү, оештыру-инструкторлык, гомуми, техник-хәзерләү, хуҗалык-төзелеш, тегермәнчелек бүлекләре, хәрби азык-төлек бюросы (1922 гә кадәр)), бүлү (гомуми бүлү, җәмәгать туклануы, транспорт, бүлүләрне оештыру, сәнәгатьне тәэмин итү, оештыру-инструкторлык бүлекләре), оештыру, финанс-хисап (финанс-хисап, финанс-смета, операцияләр-смета, гомуми бүлекләр), эшләр башкару (гомуми, мәгълүмат-инструкторлык, исәп-стат. бүлекләре), исәп-бүлү (1921 гә кадәр), адм. (1923 кә кадәр; гомуми, азык-төлек хезмәткәрләре составы һәм аларны теркәү бүлекләре), хәзерләүләр техник (1923 тән), салым (1923 тән) идарәләрен үз эченә ала. Халык ком-тлары, элеваторлар, хәзерләүләр конторалары, саклау урыннары, тегермәннәр, киптерү з-длары, складлар, савытлар-әрҗәләр ясау остаханәләре, ярдәмче пунктлар керә. ТАССР ҮБКна, ТАССР ХКСна һәм РСФСРның шундый ук Халык комис-тына буйсына. СССР ҮБК һәм ХКСның 1924 ел 9 май карары б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары ТАССР Эчке сәүдә халык комис-тына тапшырыла.

Халык комиссарлары: А.С.Изюмов (1920–1921 нең гыйн.), А.Р.Розит (1921 нең гыйн.–июне), А.Н.Злобин (1921 нең июне — 23), Г.С.Дукальский (1923–24).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ДӘҮЛӘ́Т ИМИНЛЕГЕ́ ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**, к. *Татарстан Республикасы Дәүләт иминлеге комитеты.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ДӘҮЛӘ́Т КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасының Дәүләт иминлеге комитеты.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ДӘҮЛӘ́Т ПЛАН КОМИ́ССИЯСЕ**, к. *Татарстан Республикасы Икътисад һәм сәнәгать министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ҖӘМӘГА́ТЬ ТӘРТИБЕ́Н САКЛА́У МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ҖИҢЕ́Л СӘНӘГА́ТЬ МИНИ́СТРЛЫГЫ**. ТАССР ҮБК һәм ХКСның 1932 ел 6 апрель карары нигезендә ТАССР ХХС җирлегендә ТАССР Җиңел сәнәгать халык комис-ты буларак оештырыла, ТАССР ҮБК Президиумының 1934 ел 29 август карары б-н ТАССР Җирле сәнәгать халык комис-тының Җиңел сәнәгать идарәсе (1937 нең февраленнән — ТАССР ХКС карамагында) итеп үзгәртелә, ТАССР ҮБКның 1937 ел 20 июль карары б-н Җиңел сәнәгать халык комис-ты буларак торгызыла, ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы б-н исеме ТАССР Җ.с.м. дип алыштырыла, ТАССР ЮС Президиумының 1953 ел 30 апрель карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1953 ел 30 май Указы б-н — ТАССР Җиңел һәм азык-төлек сәнәгате министрлыгы, ТАССР ЮС Президиумының 1953 ел 29 октябрь карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1953 ел 12 ноябрь Указы б-н — ТАССР Киң куллану сәнәгый товарлары министрлыгы, РСФСР ЮС Президиумының 1955 ел 1 декабрь Указы б-н — ТАССР Җ.с.м. итеп үзгәртелә. ТАССР җиңел сәнәгатенең текстиль, трикотаж, тегүчелек, киез итек-киез, күнчелек, аяк киемнәре, ат дирбияләре җитештерү, галантерея тармаклары б-н җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра һәм респ-кага буйсынулы, турыдан-туры үзенә караган пр-тиеләр б-н идарә итә. Элек Министрлык составына эшләр башкару идарәсе, планлаштыру-җитештерү, рационализацияләү, кустарь сәнәгать, хезмәт, хәзерләүләр, исәп-икътисад, кадрлар бүлекләре, киез итек-аяк киемнәре, төзелеш, исәп-хисап, эш башкарылуны тикшерү секторлары, бәяләр бюросы; 1940–50 елларда адм.-хуҗалык, җитештерү-техник, планлаштыру-икътисад, финанс, тәэминат, кадрлар бүлекләре, бухгалтерия керә. Министрлык карамагында 1930 елларда 20 ләп, 1950 елларда 17 пр-тие һәм оешма була. ТАССР ҮБКна (1938 гә кадәр), ТАССР МСна (1946 га кадәр — ХКСна) һәм РСФСРның шул ук исемдәге министрлыгына (1946 гә кадәр — Халык комис-тына) буйсына. РСФСР ЮС Президиумының 1959 ел 16 февраль Указы һәм ТАССРның 1959 ел 13 март Законы б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары *Татарстан АССР Халык хуҗалыгы советының* Җиңел сәнәгать идарәсенә тапшырыла. Халык комиссарлары һәм министрлар: Ю.П.Папёрный (1932–1934 нең апр.), Г.Г.Ганиев (1934 нең апр.–авг.), А.П.Шабалина (1937), К.К.Вәлетдинов (1938–39), Г.Г.Измайлова (1939–41), В.И.Глебов (1941–42), А.Н.Гаврилушкин (1942–46), У.Х.Аипов (1946–53), К.П.Жуков (1953–57), Г.К.Ганиев (1957–59).

Ш.у.к. *Җиңел сәнәгать.*

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ҖИҢЕ́Л СӘНӘГА́ТЬ ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**, к. *Татарстан АССР Җиңел сәнәгать министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ҖИҢЕ́Л ҺӘМ АЗЫ́К-ТӨЛЕ́К СӘНӘГАТЕ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан АССР Җиңел сәнәгать министрлыгы, Татарстан АССР Азык-төлек сәнәгате министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ҖИРЛЕ́ СӘНӘГА́ТЬ МИНИ́СТРЛЫГЫ**. Тарихы ХКСның 1918 ел 10 апрель Декреты нигезендә 1918 елның 22 апрелендә оештырылган ХХСның

Казан губерна кооперация бүлегеннән башлана. 1919 ның июлендә исеме Казан губерна ХХСның кооперация-кустарьчылык бүлеге дип алыштырыла. Бүлек Казан губерна ХХСның 1920 ел 23 июнь карары б-н — Кустарь һәм вак сәнәгать һәм кәсәбәчелек кооперациясе эшләре идарәсе («Таткустарпром»), ТАССР ХХС Президиумының 1922 ел 6 апрель карары б-н — ТАССР ХХСның кустарь эшләнмәләр Татарстан сәүдә-хәзерләүләр конторасы («Таткустторг»), ТАССР ХХС Президиумының 1922 ел 8 август карары б-н — Татарстан респ-ка сәүдә пр-тиесенең кустарь һәм вак сәнәгать бүлеге, ТАССР ҮБК Президиумының 1934 ел 29 август карары б-н — ТАССР Җирле сәнәгать халык комис-ты, ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы б-н — ТАССР Ж.с.м., ТАССР ЮС Президиумының 1953 ел 26 май карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1953 ел 30 май Указы б-н — ТАССР Җирле һәм ягулык сәнәгате министрлыгы, ТАССР ЮС Президиумының 1954 ел 7 август карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1954 ел 16 август Указы б-н — кабат ТАССР Ж.с.м., ТАССР ЮС Президиумының 1963 ел 25 июнь Указы б-н — ТАССР Азык-төлек товарлары сәнәгате министрлыгының Сәнәгать товарлары һәм сәнәгать промыселлары идарәсе, ТАССР ЮС Президиумының 1965 ел 16 февраль карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1965 ел 14 февраль Указы б-н — ТАССР МСның Җирле һәм ягулык сәнәгате идарәсе, ТАССР ЮС Президиумының 1966 ел 8 гыйнвар карары һәм РСФСР ЮСның 1966 ел 12 гыйнвар карары һәм РСФСР ЮСның 1966 ел 12 гыйнвар Указы б-н — ТАССР Ж.с.м. итеп үзгәртелә. Җирле сәнәгатьнең җиңел һәм азык-төлек сәнәгате (1937 гә кадәр), металл һәм агач эшкәртү, аяк киемнәре, мехлар, ат дирбияләре, тегүчелек эшләнмәләре, йорт җиһазлары, катыргы, мамык, баулар эшләп чыгару тармаклары һәм халык нәфис кәсепчелеге эшләнмәләре җитештерү б-н җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра; респ-кага буйсынулы, турыдан-туры үзенә караган пр-тиеләр, хуҗалык оешмалары һәм учреждениеләр б-н идарә итә; сәнәгый кооперациягә гомуми күзәтчелек һәм булышлык итү б-н шөгыльләнә. Министрлык составына башта – эшләр башкару, азык-төлек җитештерү сәнәгате идарәләре, адм.-хуҗалык, гомуми-планлаштыру бүлекләре, исәп-хисап, стат., металл эшкәртү, төзелеш материаллары, район сәнәгате секторлары, бухгалтерия; 1930 еллар ахырыннан планлаштыру-икътисад, техник, җитештерү, финанс, адм.-хуҗалык, кадрлар бүлекләре, проектлау-конструкторлык бюросы, бухгалтерия керә. Аның карамагында 1930 елларда — 28, 1980 елларда 34 пр-тие, хуҗалык исәбендәге «Татарместпром» участогы, ш.у. матди ресурсларны комплектацияләү һәм нәтиҗәле файдалану конторасы, Казан уку-укыту комб-ты була. ТАССР ҮБКна (1938 гә кадәр), ТАССР МСна (1946 га кадәр — ХКСна) һәм РСФСРның шундый ук министрлыгына (1946 га кадәр — Халык комис-тына) буйсына. ТАССР ЮС Президиумының 1989 ел 27 июнь Указы б-н бетерелә, вазифалары Татарстан җирле сәнәгатенең терр. «Татарместпром» ҖБгә тапшырыла.

Халык комиссарлары һәм министрлар: А.Г.Ганиев (1934–1937 нең марты), Г.П.Тикк (1937 нең марты–сент.), Н.П.Воржецов (1937 нең сент. – 1938), П.Д.Филимонов (1938–41), М.Я.Шкребель (1941–44), Ф.В.Шаһимәрданов (1944–46), А.А.Медведев (1946–48), М.Ш.Сираев (1948–59), У.З.Закиров (1959–60), Б.З.Мөлеков (1960–62), В.К.Успенский (1962 – 1963 нең гыйн.), В.И.Матвеев (1963 нең гыйн.–окт.), Н.Х.Козлов (1966–85), Ю.И.Демидов (1985–89).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ҖИРЛЕ́ СӘНӘГА́ТЬ ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**, к. *Татарстан АССР Җирле сәнәгать министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ҖИРЛЕ́ ҺӘМ ЯГУЛЫ́К СӘНӘГАТЕ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан АССР Җирле сәнәгать министрлыгы, Татарстан АССР Ягулык сәнәгате министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ИГЕНЧЕЛЕ́К МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ИГЕНЧЕЛЕ́К ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**, к. *Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ИНВАЛИДЛА́Р КООПЕРА́ЦИЯСЕНЕҢ КАЗА́Н ШӘҺӘРЕ́ БЕРЛЕГЕ́** (Казгоркоопинсоюз). 1945 елда оештырыла, Татарстан инвалидлар кооперациясе берлеге карамагында була. Төп максаты – шәһәр артельләренең хуҗалык-җитештерү эшчәнлегенә җитәкчелек итү, инвалидлар кооперацияләрен оештыру, ш.у. инвалидларның матди хәлен яхшырту һәм аларны эш б-н тәэмин итү. 18 артельне, 1912 әгъзаны берләштерә. Җитештерү, финанс-хисап, план-техник, тәэминат һәм сәүдә, массакүләм оештыру һ.б. бүлекләрдән тора. 1952 нең ноябре башында эшчәнлеге туктатыла.

**ТАТАРСТА́Н АССР ИНВАЛИДЛА́Р КООПЕРАТИ́В АРТЕЛЬЛӘРЕ́ БЕРЛЕГЕ́** (Таткоопинсоюз). 1924 елның июлендә Казанда ТАССР инвалидларының үзәк оешмасы буларак оештырыла. 1928 нең февраленнән — ТАССР И.к.а.б. Максаты – шәһәрләрдә һәм зур авылларда инвалид оешмаларының булганнарын берләштерү һәм яңа артельләр оештыру, инвалидларны остаханәләр эшчәнлегенә тарту, мәдәни-массакүләм ял сәгатьләре оештыру. Нигездә, сугыш, хезмәт инвалидларын һәм өлкәннәрне берләштерә. 1953 нең сентябрендә эшчәнлеге туктатыла.

**ТАТАРСТА́Н АССР ИТ ҺӘМ СӨТ СӘНӘГАТЕ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**. ТАССР ЮС Президиумының 1939 ел 10 сентябрь Указы нигезендә ТАССР Ит һәм сөт сәнәгате халык комис-ты буларак оештырыла, ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы б-н ТАССР И.һ.с.с.м. итеп үзгәртелә. Җирле әһәмияткә ия ит, йомырка-кош, сөт, май, сыр, җилем-май җитештерү сәнәгате б-н җитәкчелек итә. Бухгалтерияне, адм.-хуҗалык, планлаштыру-финанс, җитештерү-техник, кадрлар бүлекләрен үз эченә ала, министрлык системасына «Маслопром», «Птицепром» трестлары, Казан шәһәр сөт з-ды, 4 ит комб-ты, «Осинники» һәм «Свияжск» терлек азыгы хуҗалыклары керә. ТАССР ХКСна (1946 дан — МСна), РСФСРның шундый ук Халык комис-тына (1946 дан — министрлыгына) буйсына. СССР МСның 1950 ел 15 гыйнвар күрсәтмәсе, ТАССР ЮС Президиумының 1950 ел 30 гыйнвар карары, РСФСР ЮС Президиумының 1950 ел 7 февраль Указы б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары РСФСР Ит һәм сөт сәнәгате министрлыгына тапшырыла.

Халык комиссарлары һәм министрлар: З.З.Габделмәнов (1939–40, 1946–49), П.П.Черзор (1940–46).

Ш.у.к. *Сөт һәм сыр-май җитештерү сәнәгате, Ит эшкәртү сәнәгате.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ИТ ҺӘМ СӨТ СӘНӘГАТЕ́ ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**, к. *Татарстан АССР Ит һәм сөт сәнәгате министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР КИНОФИКА́ЦИЯ ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**. ТАССР ХКСның 1938 ел 23 август карары нигезендә ТАССР ХКС (1946 дан МС) каршындагы Кинофикация идарәсе буларак оештырыла; ТАССР МСның 1953 ел 23 июль һәм 7 август карарлары б-н ТАССР Мәдәният министрлыгының Кинофикация бүлеге итеп үзгәртелә, ТАССР МСның 1963 ел 20 август карары б-н ТАССР МС каршындагы Кинофикация идарәсе статусында торгызыла, ТАССР ЮС Президиумының 1979 ел 22 август Указы б-н исеме ТАССР К.д.к. дип үзгәртелә. Кино челтәрен үстерү, кинотеатрлар һәм кино кую җайланмаларын төзү һәм төзекләндерү, халыкка кино хезмәте күрсәтү эшчәнлеге б-н җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра. Канцелярияне, бухгалтерияне, планлаштыру-финанс, ревизия, техник, кадрлар бүлекләрен, методик кабинетны үз эченә ала. ТАССР К.д.к. системасына 37 район һәм 3 шәһәр кино челтәре (ш.и. Казандагы 14 кинотеатр һәм 55 кино кую җайланмасы, Чаллы шәһәрендәге 5 кинотеатр һәм 58 кино кую җайланмасы), Казан ремонт-сәнәгать комб-ты керә. ТАССР МСна һәм РСФСРның шундый ук Дәүләт ком-тына буйсына. ТАССР ЮС Президиумының 1988 ел 31 август Указы б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары Татарстан респ-ка кино-видео берләшмәсенә тепшырыла.

Рәисләре: В.Н.Макаров (1979–84), Р.Х.Ногманов (1984–88).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР КИҢ КУЛЛАНУ́ СӘНӘГЫ́Й ТОВАРЛАРЫ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан АССР Җиңел сәнәгать министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР КОММУНА́ЛЬ ХУҖАЛЫ́К МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан АССР Торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР КОММУНА́ЛЬ ХУ-ҖАЛЫ́К ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**, к. *Татарстан АССР Торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР КООПЕРА́ЦИЯЛӘР СОВЕТЫ́ (ШУРАСЫ́)**. 1926 елның октябрендә Казанда *Идел-Кама төбәге кооперативлары советы* җирлегендә оештырыла. Максатлары – кооперациянең төрле тармакларының һәм төрләренең эшчәнлеген оештыру һәм координацияләү, гомумкооперация мәнфәгатьләрен дәүләт һәм җәмәгать оешмаларында гәүдәләндерү. ТАССР К.с.ның югары органы — съезд, башкарма органы — президиум. 1928 дә советта төрле кооперация берлекләре: Бөгелмә а.х. берлеге, Бөгелмә берлеге, *Казан эшчеләренең үзәк кооперативы*, колхоз һәм машина оешмалары, Минзәлә берлеге, сөтчеләр, Сөтчеләр кооперациясе, Умартачылар кооперациясе, Елга эшчеләре кооперативы, Татсоюз (к. *Татарстан Республикасы Кулланучылар җәмгыятьләре берлеге*), Татарстан торак берлеге, Татарстан сунарчылар кооперациясе берлеге, Татарстан вак һөнәрчелек-кәсепчелек берлеге, Чистай а.х. берлеге һ.б., ш.у. финанс-кредит оешмалары: Бөтенсоюз кооперацияләренең Татарстан бүлеге һәм Татарстан а.х. банклары, Татарстан а.х. кредитлар союзы һ.б.ны берләштерә (барлыгы 21 оешма). 1928 нең 10 маенда Үзәк кооперативлар советы карары нигезендә эшчәнлеге туктатыла.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**ТАТАРСТА́Н АССР МӘГАРИ́Ф МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР МӘГАРИ́Ф ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**, к. *Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР МЕЛИОРА́ЦИЯ ҺӘМ СУ ХУҖАЛЫГЫ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**. РСФСР МСның 1961 ел 3 июль карары нигезендә ТАССР МС каршындагы Су хуҗалыгы идарәсе буларак оештырыла, РСФСР МСның 1965 ел 27 декабрь карары б-н — ТАССР МС каршындагы Мелиорация һәм су хуҗалыгы идарәсе, ТАССР ЮС Президиумының 1967 ел 25 июль карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1968 ел 23 гыйнвар Указы б-н ТАССР М.һ.с.х.м. итеп үзгәртелә. Татарстан терр-ясендә мелиорация һәм су хуҗалыгын үстерүдә техник сәясәтне гамәлгә ашыра, сугару, киптерү, су б-н тәэмин итү системалары төзелеше һәм алардан файдалану б-н җитәкчелек итә, су хуҗалыгы оешмаларының һәм пр-тиеләренең эшен координацияли. Канцелярияне, бухгалтерияне, планлаштыру-икътисад, хезмәт һәм хезмәт хакы, техник, капиталь төзелеш, баш механик, баш энергетик, кадрлар бүлекләрен үз эченә ала. Министрлык системасына район һәм районара мелиорация системаларыннан, сусаклагычлардан һәм авыллардагы төркемле сууткәргечләрдән файдалану идарәләре, хуҗалык исәбендәге проектлау төркемнәре, районнардагы «Сугару» («Полив») җитештерү берләшмәләре, ремонт-төзелеш оешмалары (трестлар, механикалаштырылган күчмә колонналар, хуҗалык исәбендәге участоклар), җитештерү-комплектлау идарәләре, автобазалар, тимер-бетон эшләнмәләр җитештерүче заводлар, төзелүче мелиорация объектлары дирекцияләре, Түбән Кама һәм Куйбышев сусаклагычларыннан файдалану идарәләре, «Сельхозводстрой» тресты керә. ТАССР МСна һәм РСФСРның шундый ук Министрлыгына буйсына. РСФСР МСның 1989 ел 24 июль күрсәтмәсе һәм ТАССР ЮС Президиумының 1989 ел 11 сентябрь Указы б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары «Татводмелиорация» проектлау-төзелеш-эксплуатация берләшмәсенә тапшырыла.

Министрлар: Х.К.Каратаев (1968–69), М.Ш.Шәймиев (1969–83), Г.Н.Захаров (1983–85), А.К.Самаренкин (1985–89). Ш.у.к. *Су хуҗалыгы, Мелиорация.*

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР МИНИ́СТРЛАР СОВЕТЫ́**, ТАССР (1990 елдан — ТССР) дәүләт хакимиятенең югары башкарма һәм идарә итүче органы (респ-ка хөкүмәте). СССРның 1946 ел 15 март Законы, ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы, РСФСРның 1946 ел 25 июнь Законы һәм ТАССРның 1946 ел 19 июль Законы нигезендә *Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советыннан* үзгәртеп корыла. Элек респ-ка министрлыкларының һәм башка хуҗалык һәм мәдәният учреждениеләренең эшен берләштерә; халык хуҗалыгы планнарын, респ-ка һәм җирле бюджетларны үтәүне тәэмин итү буенча җитәкчелек вазифаларын гамәлгә ашыра, җәмәгать тәртибен, дәүләт мәнфәгатьләрен һәм гражданнар хокукларын саклау буенча чаралар күрә; җирле советлар башкарма ком-тларының эшен җитәкли һәм тикшерә. 1955 тән ТАССР хөкүмәтенең вәкаләтләре киңәя башлый. ТАССРның 1978 елгы Конституциясе һәм ТАССРның «Татарстан АССР Министрлар Советы турында» 1979 ел 23 август Законы нигезендә ТАССР МС Татарстан карамагындагы дәүләт идарәсе мәсьәләләре б-н шөгыльләнә, ш.и. халык хуҗалыгы, социаль-мәдәни төзелеш һәм респ-каның башка дәүләт идарәсе өлкәләре б-н җитәкчелекне тәэмин итә; җирле советларның башкарма ком-тлары эшчәнлеге, респ-кага буйсынулы тармаклар б-н җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра; җирле буйсынудагы сәнәгать, төзелеш, а.х. пр-тиеләре һәм берләшмәләре, транспорт һәм элемтә пр-тиеләре, фәнни һ.б. учреждениеләр һәм оешмалар б-н идарә итүне оештыра; респ-ка министрлыклары, дәүләт ком-тлары һ.б. ведомстволар эшен координацияли һәм контрольдә тота; РСФСР һәм СССР дәүләт идарәсе югары органнары аша РСФСР һәм СССР карамагындагы мәсьәләләрне хәл итүдә катнаша; ТАССР карамагындагы мәсьәләләр буенча СССР һәм РСФСР буйсынуындагы пр-тиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар эшен координацияли һәм контрольдә тота һ.б. ТАССР (1990 нан — ТССР) ЮС тарафыннан рәис, аның беренче урынбасары һәм урынбасарлары, министрлар, дәүләт ком-тлары рәисләре һ.б. идарә органнары җитәкчеләре составында оештырыла. 1947 дән — 26, 1951 дән — 27, 1955 тән — 25, 1959 дан — 22, 1963 тән — 19, 1967 дән — 27, 1971 дән — 32, 1980 нән — 34, 1990 нан 29 әгъзадан тора. ТАССР (1990 нан — ТССР) ЮСна һәм аның Президиумына, РСФСР ЮСна һәм аның Президиумына, СССР МСна буйсына. ТАССР МСның төп актлары — карарлар һәм күрсәтмәләр. ТССР ЮСның 1991 ел 5 июль карары б-н *Татарстан Республикасы* (1992 гә кадәр — ТССР) *Министрлар Кабинеты* итеп үзгәртелә.

Рәисләре: С.М.Шәрәфиев (1946–50, 1957–59), М.Җ.Азизов (1950–57), Г.Ә.Әбдерәзәков (1959–66), Г.И.Усманов (1966–82), И.Х.Садыйков (1983–85), М.Ш.Шәймиев (1985–89), М.Г.Сабиров (1990–91).

*Әд.:* Хафизов Ш.Ш. Развитие советской государственности татарского народа. К., 1966; Тарнапольский Р.И. Правовые вопросы управления народным хозяйством в автономной республике: Взаимоотношения Совета Министров АССР с неподведомственными организациями. К., 1974; шул ук. Конституционные основы правового положения Совета Министров АССР. К., 1983.

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР НӘШРИЯ́Т ҺӘМ МАТБУГА́Т КОМБИНАТЫ́**, к. *Татарстан китап нәшрияты.*

**ТАТАРСТА́Н АССР СӘЛАМӘТЛЕ́К САКЛА́У ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**, к. *Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР СӘҮДӘ́ ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**, к. *Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР СОВЕТЛАРЫ́ СЪЕЗДЛАРЫ́**, 1920–37 елларда ТАССРның иң югары хакимият органнары. Респ-када дәүләт тормышындагы мөһим мәсьәләләрне хәл итәләр, аларга бирелгән хокуклар кысаларында законнар чыгаралар. Аларның вазифаларына ТАССР Конституциясен кабул итү, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү (Бөтенроссия ҮБК һәм Советларның Бөтенроссия съезды раслаганнан соң); респ-каның сәяси һәм икътисади эшчәнлеге б-н гомуми җитәкчелек итү, дәүләт керемнәрен һәм чыгымнарын контрольдә тоту; РСФСР бюджеты өлеше буларак, респ-ка бюджетын раслау; респ-ка хакимият органнары турындагы нигезләмәне раслау; барлык түбәндәге органнарның юридик актларын тикшерү, кире кагу һәм үзгәртү; финанс һәм салым мәсьәләләрен карау; ТАССР ҮБКн сайлау һәм аның әгъзалары санын билгеләү; Советларның Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия съездларына делегатлар һәм СССР ҮБКның Милләтләр Советына вәкилләр сайлау һ.б. керә. ТАССР ҮБК карары нигезендә елга кимендә — бер, аннары 2 елга бер тапкыр чакырыла; гадәттән тыш съездлар ТАССР ҮБК инициативасы б-н яки респ-каның 1/3 өлеш халкы исеменнән җирлек Советлары таләбе буенча җыела. Делегатлар билгеле бер вәкиллек нормалары буенча: Советларның кантон (1930 дан — район) съездларыннан — 10 мең кешегә 1 делегат исәбеннән, шәһәр һәм шәһәр бистәләре Советларыннан, фабрика һәм заводлардан — 2 мең кешегә 1 делегат сайлана. ТАССР Советлары съездының беренче утырышын ТАССР ҮБК рәисе ача, агымдагы эш



Татарстан АССР Советларының беренче (оештыру) съездында катнашучылар. 1920 ел, 26–27 сентябрь.

б-н җитәкчелек итү өчен 13–49 кеше составында президиум, мандат һәм редакция комиссияләре сайлана. Съездларда карарлар ачык тавыш бирү юлы б-н күпчелек тавыш нигезендә кабул ителә. ТАССР Советларының барлыгы 11 съезды уздырыла.

Татарстан АССР Советларының **1 нче** съезды 1920 нең 26–27 сентябрендә уздырыла, 348 делегат катнаша (309 — хәлиткеч тавыш, 39 — киңәшү тавышы). Съездда Вакытлы Революцион ком-т (ВРК) (рәисе С.С.Сәетгалиев) һәм аның бүлекләре (җир эшләре, социаль тәэминат, сәламәтлек саклау, халык мәгарифе) докладлары тыңлана; агымдагы момент турында, азык-төлек, хуҗалык төзелеше мәсьәләләре буенча карарлар кабул ителә; ТАССР ҮБК сайлана (рәисе Б.Х.Мансуров). К. *Татарстан АССР Советларының беренче (оештыру) съезды.*

**2 нче** съезд 1921 нең 25–28 июнендә уздырыла, 490 делегат катнаша (370 — хәлиткеч тавыш, 120 — киңәшү тавышы). ТАССР ҮБК һәм ХКС, ТАССР Игенчелек халык комис-ты, Татарстан чәчү ком-тының хисап докладлары тыңлана, агымдагы момент турында, азык-төлек мәсьәләсе торышы, азык салымы, җирле сәнәгать һәм кооперацияләр турында карарлар кабул ителә; ТАССР ҮБК сайлана (рәисе Р.Ә.Сабиров).

**3 нче** съезд 1922 нең 5–10 декабрендә уздырыла, 336 делегат катнаша (315 — хәлиткеч тавыш, 21 — киңәшү тавышы). ТАССР ҮБК һәм ХКСның хисап докладлары тыңлана; Советлар Россиясенең эчке һәм халыкара хәле турында, халык мәгарифе, ТАССРның финанс торышы, сәнәгать һәм а.х.н үстерү мәсьәләләре буенча карарлар кабул ителә; ТАССР ҮБК сайлана (рәисе Р.Ә.Сабиров).

**4 нче** съезд 1923 нең 17–24 декабрендә уздырыла, 342 делегат катнаша (315 — хәлиткеч тавыш, 27 — киңәшү тавышы). ТАССР ХКС хисабы, ТАССР ХХС, ТАССР Мәгариф һәм Финанс халык комис-тлары докладлары тыңлана, ТАССРның эчке һәм тышкы хәле, сәнәгать һәм сәүдә, респ-каның җирле бюджеты турында карарлар кабул ителә; ТАССР ҮБК сайлана (рәисе Р.Ә.Сабиров).

**5 нче** съезд 1925 нең 5–9 гыйнварында уздырыла, 436 делегат катнаша (322 — хәлиткеч тавыш, 104 — киңәшү тавышы). ТАССР ХКС, ТАССР Игенчелек халык комис-ты хисаплары, ТАССР ХХС, ТАССР Финанс халык комис-ты докладлары тыңлана; ТАССР бюджеты һәм финанслары, ТАССР сәнәгатендәге хәл турында карарлар кабул ителә; ТАССР ҮБК сайлана (рәисе Ш.Ш.Шәймәрданов).

**6 нчы** съезд 1926 ның 7–14 мартында уздырыла, 492 делегат катнаша (344 — хәлиткеч тавыш, 148 — киңәшү тавышы). СССР ХКС, РСФСР ХКС, ТАССР ХКС, ТАССР Игенчелек халык комис-ты хисаплары, ТАССР ХХС, ТАССР Финанс халык комис-ты докладлары тыңлана; ТАССР бюджеты, ТАССРда кооперация төзелеше турында карарлар кабул ителә; ТАССР Конституциясе проекты тикшерелә һәм кабул ителә (Советларның Бөтенроссия съезды тарафыннан расланмый); ТАССР ҮБК сайлана (рәисе Ш.Ш.Шәймәрданов).

**7 нче** съезд 1927 нең 15–21 мартында уздырыла, 553 делегат катнаша (312 — хәлиткеч тавыш, 241 — киңәшү тавышы). ТАССР ХКС хисабы, ТАССР Мәгариф һәм сәүдә, Эшче-крәстиян инспекциясе халык комис-тлары докладлары тыңлана; ТАССР ҮБК сайлана (рәисе М.Ә.Әхмәтшин).

**8 нче** съезд 1929 ның 3–8 маенда уздырыла, 597 делегат катнаша (333 — хәлиткеч тавыш, 264 — киңәшү тавышы). РСФСР ХКС, ТАССР ХКС хисаплары, ТАССР Мәгариф һәм Игенчелек халык комис-тлары докладлары тыңлана; ТАССРда а.х.н торгызу һәм реконструкцияләү, иген уңышын арттыру һәм мәҗбүри рәвештә иң гади агрокультура чараларын кертү, яңа алфавит — яңалиф кертү турында карарлар кабул ителә; ТАССР ҮБК сайлана (рәисе Х.И.Моратхуҗин).

**9 нчы** съезд 1931 нең 17–23 февралендә уздырыла, 612 делегат катнаша (420 — хәлиткеч тавыш, 192 — киңәшү тавышы). ТАССР ХКС хисабы, ТАССР Мәгариф һәм Игенчелек халык комис-тлары докладлары тыңлана; а.х.н социаль реконструкцияләү нәтиҗәләре һәм алдагы бурычлар, гомуми мәҗбүри уку һәм мәктәпләрне политехникалаштыру турында карарлар кабул ителә; ТАССР ҮБК сайлана (рәисе Х.И.Моратхуҗин).

**10 нчы** съезд 1934 нең 22–29 декабрендә уздырыла, 546 делегат катнаша (424 — хәлиткеч тавыш, 122 — киңәшү тавышы). ТАССР ХКС хисабы, ТАССР Мәгариф һәм Игенчелек халык комис-тлары докладлары тыңлана; ТАССРда терлекчелекне үстерү бурычлары, мәдәни төзелеш турында карарлар кабул ителә; ТАССР ҮБК сайлана (рәисе Г.Г.Байчурин).

**11 нче** съезд 1936 ның 19–25 ноябрендә һәм 1937 нең 22–25 июнендә уздырыла. 467 делегат катнаша. СССР Конституциясе проекты турында доклад тыңлана, Советларның Гадәттән тыш 8 нче Бөтенсоюз һәм 17 нче Бөтенроссия съездларына делегатлар сайлана; ТАССР Конституциясе кабул ителә.

ТАССР С.с. ТАССРның 1937 елгы Конституциясе нигезендә гамәлдән чыгарыла, функцияләре ТАССР ЮСна һәм аның Президиумына тапшырыла. Ш.у.к. *Татарстан АССР Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советының Үзәк башкарма комитеты.*

Чыг.: Образование и государственно-правовое положение Татарской АССР: Сб. док. и материалов. К., 1960.

*Әд.:* Х а ф и з о в Ш.Ш. Образование Татарской АССР. К., 1960; ш у л у к. Развитие советской государственности татарского народа. К., 1966; К а р и м о в А.М. Съезды Советов Татарии (1920–1937 гг.). К., 1967.

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР СОВЕТЛАРЫНЫ́Ң БЕРЕНЧЕ́ (ОЕШТЫРУ́) СЪЕЗДЫ́**. 1920 елның 26–27 сентябрендә Казанда уздырыла. 348 делегат катнаша, шуларның 150 се — татар, 167 се — рус, 29 кеше — төрле милләт вәкилләре. Съездның көн тәртибендә: агымдагы вазгыять (В.В.Кураев), Вакытлы революцион ком-т (ВРК) доклады (С.С.Сәетгалиев), азык-төлек мәсьәләсе (А.С.Изюмов), хуҗалык төзелеше (М.Г.Рошаль, А.И.Догадов), җир мәсьәләсе (Ю.Н.Вәлидов), социаль тәэминат (В.Исхаков), сәламәтлек саклау (К.Г.Мохтаров), халык мәгарифе (А.Алмаев) мәсьәләләре. Съезд делегатларын В.И.Ленин һәм Бөтенроссия ҮБК рәисе М.И.Калинин сәламлиләр. Һәр мәсьәлә буенча резолюцияләр кабул ителә. Агымдагы вазгыять мәсьәләсе буенча резолюциядә респ-ка үз тормышын һәм төзелешен «чиктән тыш кыен шартларда башлый» диелә. Гражданнар сугышы фронтларында Кызыл Армиянең уңышлары, «куәтле дәүләткә әверелгән, исеме алдында буржуазия калтырап торган һәм барлык илләрнең капиталистлары тарафыннан кол ителгән хезмәт ияләре горурланып һәм өмет белән караган» Совет Россиясенең абруе үсү турында әйтелә. ТАССРның тыныч яшәеше һәм үсеше Россиядә һ.б. илләрдә соц. рев-ция җиңгән очракта гына мөмкин булганга күрә, Совет Россиясенең хезмәт ияләре б-н туганнарча багланышлар аша бәйләнгән ТАССР эшчеләре һәм крәстияннәре рев-ция алдындагы бурычларын ахыргача үтәячәкләр, диелә. Революцион ком-т эшчәнлеге турындагы доклад буенча резолюция кыска була һәм, тулаем алганда, аның эшен хуплый. Азык-төлек мәсьәләсе буенча резолюция 9 пункттан тора, кискен эчтәлекле була. Анда Совет дәүләтенең азык-төлек сәясәте мөмкин булган бердәнбер сәясәт дип таныла. «ТАССРның дөрес икътисади үсеше

фәкать РСФСРның барлык терр-ясендә азык-төлек эшләре тулы үзәкләштерелгән очракта гына тәэмин ителәчәк» икәнлегe ассызыклана. Азык-төлекне бүлеп бирүне (продразвёрстка) үтәү һәрбер крәстияннең бурычы булуы хакында әйтелә. Съезд «азык-төлек б-н бүлешүне иң кечкенә таләп» дип саный һәм алдан ук аны өлешчә киметүгә яки тулысынча бетерүгә юнәлтелгән барлык омтылышларны кире кага. 5 нче пунктта әйтелгәнчә, «бүлеп бирүне (продразвёрстканы) тормышка ашырмаган өчен җаваплылык җәмгыятькә йөкләнә һәм шунлыктан бу бурычның нибары бер әгъза тарафыннан үтәлмәве бар җәмәгатьчелек запасы хисабына хәл ителә». Җир мәсьәләсе буенча резолюциядә җирләрне, басуларны, болын һәм урманнарны файдалануга кертү карала. Игенчелектә һәм терлекчелектә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруның төп юллары билгеләнә. Халык мәгарифе буенча резолюциядә халыкның проф. белем үсеше мәсьәләләренә игътибарны арттыруга басым ясала. Беренче урынга мәктәп һәм укытучы кадрлар, махсус китапларны татар һәм чуаш телләренә тәрҗемә итү мәсьәләсе куела. Гомуми хезмәт йөкләмәсе турындагы резолюциядә «эшчеләр хезмәт җитештерүчәнлеген арттырырга тиеш. Крәстияннәр дәүләт тарафыннан билгеләнгән йөкләмәләрне үтәргә бурычлы» диелә. Съездда 59 кешедән торган ТАССР ҮБК сайлана (С.С.Сәетгалиев, Б.Х.Мансуров, М.Х.Солтангалиев, К.Г.Мохтаров, А.И.Догадов, К.Х.Исмаев, А.П.Таняев, Г.Б.Баһаветдинов, М.Ш.Шаһиәхмәтов, Х.З.Гайнуллин, В.С.Шәфигуллин, Р.Ә.Сабиров һ.б.). Ш.у.к. *Татарстан АССР Үзәк башкарма комитетының беренче пленар утырышы*.

Чыг.: Образование Татарской АССР: Сб. док. и материалов. К., 1960.

*Әд.:* Хайрутдинов Р.Г. Трудное возрождение. К., 1992; Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999; шул ук. История национальной государственности татарского народа и Татарстана. К., 2000.

**ТАТАРСТА́Н АССР СОЦИА́ЛЬ ТӘЭМИНА́Т ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**, к. *Татарстан Республикасы Социаль яклау министрлыгы*.

**ТАТАРСТА́Н АССР ТӘЭМИНА́Т ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**. ТАССР ҮБК һәм ХКСның 1931 ел 4 гыйнвар карары нигезендә оештырыла, эшчәнлеге 1931 нең 11 гыйнварыннан башлана. Хәзерләүләр һәм халыкны азык-төлек һәм сәнәгать товарлары б-н тәэмин итү б-н шөгыльләнә, товар бәяләрен көйли, респ-каның азык-төлек сәнәгатен күтәрү һәм реконструкцияләүгә җитәкчелек итә. Элек — эшләр башкару идарәсен, планлаштыру-икътисад, исәп һәм хисап, сәүдә, хәзерләүләр, тәэминат, сәнәгать, башкаруны тикшерү, халык хуҗалыгы планын үтәү, кадрлар һәм махсус секторларны, рационализаторлык һәм уйлап табу бюросын; янгыннан саклану инспекциясен, 1934 тә эшләр башкару, сәүдә һәм тәэминат, сәнәгать идарәләрен, бухгалтерияне, оештыру-инструкторлык төркемен, хәзерләүләр, кадрлар, махсус секторларны, санитария, сыйфат инспекцияләрен, янгыннан саклану-каравыл сагын үз эченә ала. Халык комис-ты системасына 250 ләп азык-төлек җитештерү сәнәгате пр-тиесе, 5500 гә якын сәүдә оешмасы, 20 дән артык кабул итү-хәзерләүләр пункты һ.б. керә. ТАССР ҮБКна, ТАССР ХКСна һәм РСФСРның шундый ук Халык комис-тына буйсына. ТАССР ҮБК Президиумының 1934 ел 29 август карары б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары ТАССР Җирле сәнәгать халык комис-тына һәм ТАССР Эчке сәүдә халык комис-тына тапшырыла.

Халык комиссарлары: Н.И.Анцишкин (1931 нең гыйн.–апр.), М.И.Залипский (1931 нең апр.–1934). *Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ТЕРЛЕКЧЕЛЕ́К МИНИ́СТРЛЫГЫ**. ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 3 май Указы нигезендә оештырыла. Респ-каның терлекчелек хуҗалыгы б-н идарә итүне гамәлгә ашыра. Кама алды, Көньяк, Көнчыгыш, Шәһәр яны җитештерү-терр. идарәләрен, зоотехния, вет., ат үрчетү, кошчылык һәм вак терлекчелек идарәләрен, адм.-хуҗалык, кадрлар, планлаштыру-финанс, төзелеш һәм механикалаштыру, терлек азыгы бүлекләрен, махсус секторны үз эченә ала. Министрлык системасына район терлекчелек бүлекләре, «Татветснабсбытторг», «Сельхозпромснаб» оешмалары, ипподром, 3 терлекчелек хәзерләүләр конторасы, 2 дәүләт нәсел үрчетү пр-тиесе, 2 өлкә һәм 16 районара вет. лаб-ясе, терлекчелек буенча өлкә тәҗрибә станциясе, Казан вет. фәнни-тикшеренү ин-ты, 2 техникум, 3 а.х. һәм 6 районара колхоз мәктәбе керә. ТАССР МСна һәм РСФСРның шундый ук министрлыгына буйсына. ТАССР ЮС Президиумының 1947 ел 3 март Указы б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары ТАССР А.х. министрлыгына тапшырыла.

Министр — Ә.М.Хөсәенов (1946–47). *Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ТОРА́К-КОММУНА́ЛЬ ХУҖАЛЫ́К МИНИ́СТРЛЫГЫ**. Тарихы Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары Казан советы гомуми җыелышының 1918 ел 21 декабрь карары нигезендә губерна башкарма ком-тының коммуналь бүлеге оештырылудан башлана; ТАССР ҮБКның 1920 ел 28 сентябрь карары б-н ТАССР Эчке эшләр халык комис-тының Коммуналь хуҗалык идарәсе итеп үзгәртелә, ТАССР ҮБК һәм ХКСның 1923 ел 13 апрель карары б-н исеме ТАССР ХКС каршындагы Коммуналь хуҗалык идарәсе дип алыштырыла, ТАССР ХКСның 1926 ел 7 июль карары б-н — ТАССР Эчке эшләр халык комис-тының Баш коммуналь хуҗалык идарәсе, ТАССР ҮБК һәм ХКСның 1930 ел 20 декабрь карары б-н — ТАССР ХКС каршындагы Баш коммуналь хуҗалык идарәсе, ТАССР ХКСның 1931 ел 28 август һәм ТАССР ҮБК Президиумының 1931 ел 24 ноябрь карарлары б-н — ТАССР Коммуналь хуҗалык халык комис-ты, ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы б-н — ТАССР Коммуналь хуҗалык министрлыгы, ТАССР ЮС Президиумының 1971 ел 15 сентябрь Указы б-н ТАССР Т.-к.х.м. итеп үзгәртелә. Җирле Советларның торак фондын, кунакханәләрне, электр станцияләрен, мунчаларны, кер юу йортларын су б-н тәэмин итү, төзү, төзекләндерү һәм файдалану, тротуарларны, урам түшәмәләрен һәм күперләрне төзү һәм төзекләндерү, газлаштыру, яшелләндерү, шәһәр транспортыннан файдалану мәсьәләләре б-н шөгыльләнә, шәһәрләрдә һәм эшчеләр посёлокларында төзелеш, алардагы биналарны һ.б. корылмаларны инвентаризацияләү эшләре алып бара, коммуналь трестлар һәм пр-тиеләр эшчәнлеге б-н җитәкчелек итә. Элек гомуми, планлаштыру-икътисад, торак һәм коммуналь хуҗалык, шәһәрләрне һәм посёлокларны планлаштыру һәм аларның корылышы, төзелеш идарәләрен; төзекләндерү, исәп һәм хисап, техник инвентаризацияләү секторларын; исәп һәм кадрлар әзерләү бүлеген; үзәк бухгалтерияне үз эченә ала. 1960–80 елларда министрлык составына бухгалтерия, гомуми торак хуҗалыгы, коммуналь пр-тиеләр, планлаштыру-финанс, шәһәрләрне һәм торак пунктларны газлаштыру бүлекләре; техник инвентаризацияләү секторы керә. ТАССР Т.-к.х.м.на ремонт-төзелеш, гидротехник корылмалар идарәләре; проект-смета бюросы; шәһәрләр, эшчеләр посёлоклары һәм район үзәкләренең торак-коммуналь бүлекләре һәм идарәләре; трестлар, конторалар һ.б. пр-тиеләр буйсынулы була. ТАССР ҮБКна (1938 гә кадәр), ТАССР МСна (1946 га кадәр ХКСна) һәм РСФСРның шундый ук министрлыгына (1946 га кадәр Халык комис-тына) буйсына. ТАССР ЮС Президиумының 1989 ел 31 май Указы б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары ТАССР Торак-коммуналь хуҗалыгы ҖБгә тапшырыла.

Халык комиссарлары һәм министрлар: Г.В.Аитов (1931–32), В.В.Маликов (1932–33), Н.И.Никольский (1933–34), Г.К.Касыймов (1934–35), М.Х.Исхаков (1935–1938 нең февр.), М.Г.Галиев (1938 нең февр.–апр.), Н.И.Сорвин (1938 нең апр.–1940), К.М.Пелиппенко (1940–43), К.В.Данько (1943–47), Я.И.Исламов (1947–53), Л.Н.Котов (1953–1963 нең гыйн.), Б.Н.Донауров (1963 нең гыйн.–июне), А.А.Кириллович (1963 нең июне–1965), П.Д.Тунаков (1965–66), В.С.Иванов (1966–80), Ю.П.Акимов (1980–89).

Ш.у.к. *Коммуналь хуҗалык*.

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ТУКУ́-ТЕГҮ́ КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́ КООПЕРА́ЦИЯСЕ БЕРЛЕГЕ́** (Татшвейтекстильпромсоюз). ТАССРның мех әйберләр тегү кәсепчелеге кооперациясе берлеге буларак, 1932 елның декабрендә Казанда оештырыла. 1952 нең августыннан Казан өлкәсе туку-тегү кәсепчелеге берлеге, 1953 нең августыннан ТАССР туку-тегү кәсепчелеге кооперациясе берлеге итеп үзгәртелә. Артельләрнең җитештерү һәм финанс эшчәнлегенә җитәкчелек итә. 32 артельне берләштерә. *Татарстан кәсепчелек кооперативлары советына* буйсына. 1956 ның сентябрендә бетерелә.

**ТАТАРСТА́Н АССР УРМА́Н СӘНӘГАТЕ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**. ТАССР ЮС Президиумының 1939 ел 5 май Указы б-н «Татлес» һәм «Татдрев» трестлары җирлегендә ТАССР Урман сәнәгате халык комис-ты бу-

ларак оештырыла. Секретариатны, урман хәзерләүләр һәм сал агызу, агач эшкәртү идарәләрен; гомуми планлаштыру, финанс, проектлау-техник һәм капиталь төзелеш, адм.-хуҗалык, урман б-н тәэмин итү һәм сату, сәүдә, кадрлар бүлекләрен; бухгалтерияне, махсус секторны, стат. төркемен үз эченә ала. Аңа 2 трест, 12 урман сәнәгате хуҗалыгы, 10 урман з-ды, урман күчерү базасы, йорт җиһазлары ф-касы, үзәк матди-техник база, проектлау-тикшеренүләр бюросы буйсына. Халык комис-ты ТАССР ХКСна һәм РСФСРның шундый ук Халык комис-тына буйсына.

ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы б-н ТАССР Урман сәнәгате халык комис-тының исеме ТАССР У.с.м. дип алыштырыла, ТАССР ЮС Президиумының 1949 ел 14 апрель Указы б-н — ТАССР Урман һәм кәгазь сәнәгате министрлыгы, ТАССР ЮС Президиумының 1951 ел 26 март Указы б-н — кабат ТАССР У.с.м., ТАССР ЮС Президиумының 1953 ел 30 апрель карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1953 ел 30 май Указы б-н — ТАССР Урман һәм кәгазь сәнәгате министрлыгы, ТАССР ЮС Президиумының 1954 ел 23 июль карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1954 ел 5 август Указы б-н ТАССР У.с.м. итеп үзгәртелә. Урман хәзерләүләр һәм сал агызуларны оештыру, урман кисү һәм агач эшкәртү сәнәгатен үстерү, йорт җиһазлары җитештерү, урман кисү фондын эшләү, җитештерү процессларын механикалаштыру һ.б. б-н шөгыльләнә. Аның составына бухгалтерия; адм.-хуҗалык, урман хәзерләүләр һәм сал агызу, урман кисү һәм агач эшкәртү буенча җитештерү-техник, планлаштыру-икътисад, капиталь төзелеш, финанс, кадрлар, хезмәт һәм хезмәт хакы бүлекләре керә. Министрлык системасында «Татспецзаг» һәм «Татлесдрев» (1954 кә кадәр) трестлары, 16 урман сәнәгате хуҗалыгы, 3 (1954 кә кадәр — 6) урман з-ды, урман комб-ты, йорт җиһазлары ф-касы (1954 кә кадәр), үзәк ремонт-механика остаханәсе, үзәк матди-техник база, төзелеш идарәсе керә. ТАССР МСна һәм РСФСРның шундый ук Министрлыгына буйсына. РСФСР ЮС Президиумының 1955 ел 13 июль Указы нигезендә гамәлдән чыгарыла, вазифалары «Татлес» трестына тапшырыла.

Халык комиссарлары һәм министрлар: М.Г.Газизов (1934–40), П.М.Владимиров (1940–42, 1948–55), Н.И.Коровин (1942–43), Г.В.Шипунов (1943–48).

Ш.у.к. *Урман, агач эшкәртү һәм целлюлоза-кәгазь сәнәгате.* *Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР УРМА́Н СӘНӘГАТЕ́ ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**, к. *Татарстан АССР Урман сәнәгате министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР УРМА́Н ҺӘМ КӘГА́ЗЬ СӘНӘГАТЕ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**, *Татарстан АССР Урман сәнәгате министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ҮЗӘ́К БАШКАРМА́ КОМИТЕТЫНЫ́Ң БЕРЕНЧЕ́ ПЛЕНА́Р УТЫРЫШЫ́**. 1920 елның 28 сентябрендә Казанда уздырыла. Утырышта ТАССР ҮБК Президиумы сайлана (рәисе — Б.Х.Мансуров, рәис урынбасары — А.С.Самохвалов, әгъзалары – А.П.Таняев, Х.З.Гайнуллин, А.Копнов, А.А.Денисов, Н.Я.Яруллин) һәм ТАССР хөкүмәте — ХКС оештырыла (рәисе — С.С.Сәетгалиев, әгъзалары — Г.Й.Измайлов, А.С.Изюмов, М.Г.Рошаль, Х.Ш.Солтанов, А.Н.Нехотяев, В.Исхаков, А.И.Бочков, А.И.Догадов, К.Г.Мохтаров, Ю.Н.Вәлидов, А.С.Гордеев, Г.Иванов, К.Г.Хахарев, И.Я.Вейцер).

*Әд.:* Хайрутдинов Р.Г. Трудное возрождение. К., 1992.

**ТАТАРСТА́Н АССР ФИНА́НС ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**, к. *Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЛАРЫ́**, 1920–46 елларда респ-каның тармаклар б-н дәүләт идарәсе органнары. Халык хуҗалыгының, социаль-мәдәни төзелешнең һәм адм.-сәяси эшчәнлекнең аерым тармаклары б-н идарә итүне гамәлгә ашыра. ТАССР Халык комис-тларының хокукый асылы Бөтенроссия ҮБКның һәм РСФСР ХКСның «Автономияле Татарстан Социалистик Совет Республикасы хакында» Декретында (1920), РСФСР һәм ТАССР Конституцияләрендә, аерым Халык комис-тлары хакындагы нигезләмәләрдә билгеләнә. ТАССР Х.к.ның эшчәнлеге ТАССР ХКС тарафыннан берләштерелә һәм юнәлтелә. РСФСР Халык комис-тларына, ТАССР ҮБКна (1938 дән ЮСна), ТАССР ХКСна буйсыналар. ТАССР ХКС Рәисе тәкъдиме б-н элек ТАССР ҮБК, 1938 дән ТАССР ЮС, сессияләр арасында аның Президиумы тарафыннан билгеләнүләрен һәм вазифаларыннан азат ителүләрен респ-ка ЮС раслаган халык комиссарлары җитәкчелек итә. Татарстан АССРда азык-төлек (1920–24), азык-төлек сәнәгате (1937 дән), дәүләт куркынычсызлыгы (1941, 1943 тән), җиңел сәнәгать (1932 дән), җирле сәнәгать (1934 тән), игенчелек (1920 дән), ит һәм сөт сәнәгате (1939 дан), коммуналь хуҗалык (1931 дән), мәгариф (1920 дән), сәламәтлек саклау (1920 дән), социаль тәэминат (1920 дән), сәүдә (1924 дән), тәэминат (1931–34), урман сәнәгате (1939 дан), финанс (1920 дән), хезмәт (1920–33), эчке эшләр (1920 дән), эшче-крәстияннәр инспекциясе (1920–34), юстиция (1920 дән) халык комис-тлары була. ТАССР Х.к. СССРның 1946 ел 15 март Законы, ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы, РСФСРның 1946 ел 25 июнь Законы һәм ТАССР ЮСның 1946 ел 19 июль карары б-н ТАССР министрлыклары итеп үзгәртелә (к. *Татарстан Республикасы министрлыклары*).

*Әд.:* Хафизов Ш.Ш. Развитие советской государственности татарского народа. К., 1966.

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ХАЛЫ́К КОМИССАРЛАРЫ́ СОВЕТЫ́** (ХКС), ТАССРда 1920–46 елларда дәүләт хакимиятенең югары башкарма һәм боеручы органы. 1920 нең 28 сентябрендә *Татарстан АССР Үзәк Башкарма Комитетының беренче пленар утырышында* С.С.Сәетгалиев (ХКС рәисе), Г.Й.Измайлов (эчке эшләр халык комиссары), М.Г.Рошаль (ХХС рәисе), Х.Ш.Солтанов (мәгариф халык комиссары), А.Н.Нехотяев (юстиция халык комиссары), В.И.Исхаков (социаль тәэминат халык комиссары), А.И.Бочков (Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советының Казан губерна башкарма ком-ты рәисе урынбасары), А.И.Догадов (Татарстан Профсоюзлар Советы рәисе), К.Г.Мохтаров (сәламәтлек саклау халык комиссары), Ю.Н.Вәлидов (игенчелек халык комиссары), А.С.Гордеев (финанс халык комиссары), Г.М.Иванов (Контрреволюция, спекуляция һәм вазифаи җинаятьләр б-н көрәш буенча бөтен Татарстан гадәттән тыш комиссиясе рәисе), К.Г.Хахарев (Татарстан хәрби комиссары), И.Я.Вейцер (ХКС Президиумы әгъзасы) составында оештырыла. Башта ХКС ТАССР ҮБК тарафыннан бирелгән вәкаләтләр чикләрендә респ-ка б-н гомуми идарә итү хокукына ия була. ҮБКның башкарма органы буларак, ул *Татарстан АССР халык комиссариатлары*, Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары җирле советларының башкарма ком-тлары эшчәнлегенә җитәкчелек итә; респ-ка законнарын эшләүдә катнаша (декретлар һәм карарлар чыгару хокукына ия була); респ-ка халык хуҗалыгы үсеше планын карый, аны ТАССР ҮБК һәм аның Президиумы раславына кертә; респ-ка һәм җирле бюджетларны, аларның үтәлеше турындагы хисапларны беренчел тикшерә; аерым терр. берәмлекләр һәм ведомстволарга акча бүлү б-н шөгыльләнә; дәүләт салымнарыннан һәм керемнәреннән респ-ка ихтыяҗларына күчереләчәк акчалар күләме буенча нәтиҗәләр чыгара һәм аларны ТАССР ҮБК карамагына кертә; Татарстан терр-ясендә урнашкан пр-тиеләр һәм оешмалар (хәрәкәттәге армия учреждениеләреннән тыш) эшчәнлеген контрольдә тота һ.б. ТАССР ҮБКна һәм аның Президиумына караган хакимият вәкаләтләренең зур өлеше дәүләт идарәсенең барлык респ-ка органнары б-н югарыдан җитәкчелек итү вазифаларына керешкән ТАССР ХКСна күчә. Ул ТАССР халык комис-тларының, бөтенсоюз һәм союз-респ-ка халык комис-тларының үз карамагында булган хуҗалык һәм мәдәният учреждениеләренең эшен берләштерә һәм юнәлтә; халык хуҗалыгы планын, респ-ка һәм җирле бюджетларны гамәлгә ашыру, җәмәгать тәртибен тәэмин итү, дәүләт мәнфәгатьләрен һәм гражданнар хокукларын саклау буенча чаралар күрә; хезмәт ияләре җирле советларының башкарма ком-тлары эшчәнлеге б-н җитәкчелек итә; карарлар, боерыклар чыгара һәм аларның үтәлешен контрольдә тота һ.б. ХКСның персональ составын рәис, рәис урынбасарлары, халык комиссарлары һ.б. идарә органнары җитәкчеләре составында ТАССР ҮБК (1938 гә кадәр), ТАССР ЮС (1938 дән) раслый. 1920 дән — 15, 1922 дән — 13, 1923 тән — 16, 1925 тән — 19, 1927 дән — 17, 1929 дан — 18, 1931 дән — 16, 1934 тән — 12, 1938 дән 16 әгъзадан тора. ХКС каршында Икътисад комиссиясе (ЭКОСО) (1921–26), үзәк эквивалент (1921–23), экспертиза (1921,

1928–35), закон фаразлары (1921–27), йортларны һәм корылмаларны демуниципализацияләү (1924–29) комиссияләре һ.б. эшли. ТАССР Советлары Съездына, ТАССР ҮБКна һәм аның Президиумына, Советларның Бөтенроссия Съездына, Бөтенроссия ҮБКна һәм аның Президиумына (1938 дән), РСФСР ХКСна (1920 дән) һәм СССР ХКСна (1923 тән) буйсына. СССРның 1946 ел 15 март Законы, ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы, РСФСРның 1946 ел 25 июнь Законы һәм ТАССРның 1946 ел 19 июль Законы б-н *Татарстан АССР Министрлар Советы* итеп үзгәртелә.

Рәисләре: С.С.Сәетгалиев (1920–21), К.Г.Мохтаров (1921–24), Х.З.Габидуллин (1924–27), Ш.Ш.Шәймәрданов (1927–28), К.Х.Исмаев (1928–30), К.А.Абрамов (1930 – 1937 нең июле), Ә.М.Дәүләтъяров (1937 нең сент.–дек.), Ә.Х.Тынчеров (1938–40), С.Х.Гафиятуллин (1940–43), С.М.Шәрәфиев (1943–46). Ш.у.к. *Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты*.

Чыг.: Конституция (Основной Закон) Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. К., 1937; Образование и государственно-правовое положение Татарской АССР: Сб. док. и материалов. К., 1960. Ч. 1.

*Әд.:* Хафизов Ш.Ш. Развитие советской государственности татарского народа. К., 1966.

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ХАЛЫ́К ХУҖАЛЫГЫ́ КАЗАНЫШЛАРЫ́ КҮРГӘЗМӘСЕ́** (ТАССР ВДНХсы). 1956 елда а.х., сәнәгать, төзелеш, транспорт, фән, мәдәният, сәламәтлек саклау, халык мәгарифе казанышларын күрсәтү өчен оештырыла. Иң беренче комплексларның берсе Казанда 1909 ның июнендә Арча кырында ачыла һәм вак, эре, а.х. сәнәгатьләре, утка чыдам төзелеш, янгынга каршы эш бүлекләрен үз эченә ала. Анда Россиянең 30 губернасыннан 2500 экспонент, ш.у. Германия, Англия, Финляндиянең зур фирмалары үз продукцияләрен күргәзмәгә куя. 1950 гә ТАССРның 30 еллыгына беренче Милли күргәзмә ачыла, анда ТАССРның сугыштан соңгы казанышлары күрсәтелә. Алардан аермалы буларак, ТАССР ВДНХсы беренче даими эшләүче 11 павильонлы күргәзмәгә әверелә (ш.и. «Авыл хуҗалыгы», «Нефть», «Төзелеш», «Икмәк продуктлары», «Азык сәнәгате», «Авыл хуҗалыгы техникасы», «Халык мәгарифе», «Фән» павильоннары). Аның катнашучылары: алдынгы колхоз һәм совхозлар, завод һәм фабрикалар, төзелеш һәм транспорт оешмалары, фәнни учреждениеләр, югары һәм урта белем бирү уку йортлары, мәдәни үзәкләр, а.х. һәм сәнәгать алдынгылары, галимнәр. Ел саен тармакара һәм аерым тармакларның тематик, респ-ка, төбәк, халыкара күргәзмәләр; сәнәгать һәм а.х. житештерүе үсешенең иң мөһим проблемалары буенча экспозицияләр һәм аларның тармакларына хезмәт күрсәтүче, алар җирлегендәге фәнни-җитештерү конференцияләре, семинарлар, алдынгы тәҗрибә мәктәпләре, тематик һәм гомуми экскурсияләр, ш.у. галимнәр һәм белгечләр б-н очрашулар уздырыла. Ел саен лекцияләр, аңгәмә һәм экскурсияләр, консультация һәм аңлату эшләре б-н уздырыла торган яшелчә, җиләк-җимеш культуралары үсентеләренең күзгә күргәзмәләре күмәк бакчачылык, яшелчәчелек һәм чәчәк үстерү хуҗалыгы үсешенә ярдәм итә. ВДНХ үсемлекчелек, терлекчелектә, а.х.н механикалаштыруда фән һәм алдынгы тәҗрибә казанышларын пропагандалауда аеруча зур роль уйный. Ел саен ВДНХга 100 меңгә кадәр кеше килеп китә. Иң яхшы экспонентлар мактау дипломнары һәм 1 нче, 2 нче, 3 нче дәрәҗә дипломнар б-н бүләкләнә. 1990 да Мәгълүмат-коммерция күргәзмә берләшмәсе (ВИКО) итеп үзгәртелә, 1998 дән — «*Казан ярминкәсе*».

**ТАТАРСТА́Н АССР ХАЛЫ́К ХУҖАЛЫГЫ́ СОВЕТЫ́** (ТАССР ХХС), ТАССРда 1918–32, 1957–62 елларда сәнәгать һәм төзелеш б-н дәүләт идарәсен гамәлгә ашыру органы. Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна советының 1918 ел 19 февраль карары нигезендә Казан губерна ХХС буларак оештырыла (1918 нең 20 июненнән эшли башлый); Бөтенроссия ҮБК һәм РСФСР ХКСның 1920 ел 27 май Декреты һәм ТАССР ҮБКның 1920 ел 28 сентябрь карары б-н ТАССР ХХС итеп үзгәртелә. Элек сәнәгатьне национализацияләү, җитештерүне җайга салу, сәнәгать продукциясен бүлү б-н җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра, хәрби ихтыяҗлар буенча хәзерләүләр эшләрен башкара; 1920 елларда респ-кага буйсынулы пр-тиеләр, җирле трестлар һәм дәүләт сәүдә оешмалары б-н җитәкчелек итә, кооператив һәм хосусый сәнәгать пр-тиеләре эшчәнлеген контрольдә тота; 1920 еллар ахырыннан ш.у. җирле сәнәгатьне реконструкцияләү, яңа пр-тиеләр төзү һәм аларны файдалануга тапшыру б-н шөгыльләнә. Президиумны, тармак бүлекләрен (1918 дә — 12, 1920 дә — 36), 1920 еллар башында — оештыру-адм., финанс-хисап, җитештерү, исәп һәм стат., 1920 еллар уртасыннан — эшләр башкару (гомуми, финанс-хуҗалык бүлекләре), дәүләт сәнәгате (җитештерү-техник, ягулык, планлаштыру-икътисад, стат., икътисад һәм һөнәри-техник белем, кустарь сәнәгате һәм кәсепчелек кооперациясе, кантон сәнәгате, сәнәгатьне мобилизацияләү бүлекләре) идарәләрен, мобилизация, рационализация бюроларын, бухгалтерияне, 1930 еллар башында эшләр идарәсен, бухгалтерияне, махсус, рационализация һәм уйлап табулар бюроларын, ягулык һәм энергетика, башкарылуны тикшерү, район һәм кустарь сәнәгате, капиталь төзелеш, тәэминат һәм транспорт, план-җитештерү секторларын үз эченә ала. Губерна (1920 дән — респ-ка) ХХС карамагында өяз ХХСлары (1918–20), кантон (1920–30) һәм район (1930 дан) вәкаләтле вәкилләре, ш.у. металл эшкәртү, химия, урман, агач материаллары сәнәгатьләре һ.б. тармаклар пр-тиеләре (Гражданнар сугышы чорында — 485, 1920 елларда — 90 нан артык) була. РСФСР Югары ХХСна, ТАССР ҮБКна, ТАССР ХКСна буйсына. ТАССР ХХС СССР ҮБК һәм ХКСның 1932 ел 5 гыйнвар һәм 27 март, ТАССР ҮБК һәм ХКСның 1932 ел 6 апрель карарлары б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары *Татарстан АССР Җиңел сәнәгать халык комиссариатына* тапшырыла.

СССРның икътисади адм. районнар б-н идарә итүдә терр. принципка күчүе нәтиҗәсендә СССР ЮС Президиумының 1957 ел 10 март Указы һәм СССР МСның 1957 ел 22 май карары б-н Татарстан икътисади адм. районы ХХС оештырыла (үзенең эшчәнлеген 1957 нең июнь–июлендә башлый). Ул районнарның специальләшүен үстерү, эчке чимал һ.б. ресурсларны мобилизацияләү, пр-тиеләрнең техник яктан җиһазлану дәрәҗәсен күтәрү б-н шөгыльләнә. ХХСның тармак һәм функциональ бүлекләре һәм идарәләре була. Тармак идарәләре нефть, энергетика, машина төзелеше, химия, урман, йорт җиһазлары һәм агач эшкәртү, җиңел, азык-төлек, ит һәм сөт сәнәгатьләренең, төзелешнең һәм төзелеш материаллары сәнәгатенең, комплектлау, тәэминат һәм сату, эшчеләр тәэминаты, транспорт өлкәләренең тиңдәш пр-тиеләрен берләштерә. ХХСның функциональ юнәлешенә җитештерү-техник идарә (яңа техника, җитештерү, баш механик һәм энергетик, фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре, хезмәт куркынычсызлыгы бүлекләре), адм.-хуҗалык, планлаштыру-икътисад, финанс, капиталь төзелеш, җитәкче кадрлар һәм уку-укыту оешмалары, хезмәт һәм хезмәт хакы, тышкы багланышлар һәм кооперацияләү бүлекләре, үзәк бухгалтерия керә; алар барысы да координацияләү, планлаштыру эшчәнлеге алып баралар, респ-каның 175 пр-тиесе тарафыннан ХХС карарларының үтәлешен контрольдә тоталар. ХХС каршында тармак идарәләренә туры килгән секцияләр составындагы техник-икътисади совет эшли. РСФСР МСна һәм 1960 тан РСФСР ХХСна да буйсына. РСФСР ЮС Президиумының 1962 ел 25 декабрь Указы һәм РСФСР МСның 1962 ел 26 декабрь карары б-н Татарстан икътисади адм. районы ХХС Урта Идел икътисади адм. р-ны ХХСна кертелә; үзәге — Куйбышев ш. (Самара ш.). КПСС ҮКның 1965 елгы сентябрь Пленумында сәнәгать б-н идарә итүнең тармак системасына кире кайтуы турында карар кабул ителә. СССРның 1965 ел 2 октябрь Законы б-н халык хуҗалыгы советлары бетерелә һәм сәнәгать министрлыклары оештырыла. Рәисләре: С.М.Брауде (1918–19), М.Г.Рошаль (1919–21), В.В.Сериков (1921–22), Е.Н.Забицкий (1922 — 1924 нең гыйн.), А.Н.Злобин (1924 нең гыйн. — июнь), М.С.Мансырев (1924 нең июне — дек.), Г.С.Дукальский (1925–1927 нең февр.), Я.С.Щербинин (1927 нең февр. — нояб.), И.А.Булгаков (1927 нең нояб. — 1929 ның гыйн.), А.Г.Ганиев (1929 ның гыйн. — дек.), А.А.Терский (1929 ның дек. — 1930), Ю.Н.Паперный (1930–32), А.Т.Шмарёв (1957–60), С.Л.Князев (1960–63).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ХЕЗМӘ́Т ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**. Тарихы Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна советының 1917 ел 16 ноябрь карары нигезендә оештырылган, 1917 нең 17 ноябреннән эшкә керешкән Казан губерна хезмәт комис-тыннан башлана. Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна советы гомуми җыелышының 1918 ел 26 февраль карары б-н

Казан Совет Эшче-Крәстиян Респ-касының Хезмәт комис-ты итеп үзгәртелә; Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советы Казан губерна башкарма ком-тының 1918 ел 16 май һәм Казан губерна ХКСның 1918 ел 3 июнь карарлары б-н Казан губерна хезмәт комис-ты буларак торгызыла, Казан губерна революцион ком-тының 1918 ел 14 сентябрь һәм Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы Казан губерна башкарма ком-тының 1918 ел 15 октябрь карарлары б-н исеме губерна башкарма ком-тының хезмәт бүлеге дип алыштырыла; Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы Казан губерна башкарма ком-тының 1918 ел 29 ноябрь карары б-н — губерна башкарма ком-тының хезмәт һәм социаль тәэминат бүлеге, Бөтенроссия ҮБКның 1920 ел 21 апрель карары б-н — кабат губерна башкарма ком-тының хезмәт бүлеге, Бөтенроссия ҮБКның һәм РСФСР ХКСның 1920 ел 27 май Декреты, ТАССР ҮБКның 1920 ел 28 сентябрь карары б-н — ТАССР Х.х.к., ТАССР ҮБКның 1927 ел 25 март карары б-н — ТАССР Хезмәт һәм социаль тәэминат халык комис-ты һәм ТАССР ҮБКның 1928 ел 6 октябрь карары б-н ТАССР Х.х.к. итеп үзгәртелә. Халык комис-ты хезмәткә кагылышлы законнарның кулланылуын күзәтә, хезмәт шартларын һәм базарын көйли, яллы эшчеләр мәнфәгатьләрен тәэмин итә, эшсезлек б-н көрәшә, хезмәтне саклауны гамәлгә ашыра, социаль иминиятләштерү һ.б. б-н шөгыльләнә. Аның вәкаләтләре респ-кадагы дәүләти һәм хосусый пр-тиеләргә, оешмаларга тарала. Эшләр башкару, хезмәтне оештыру һәм савыктыру (1933 тән) идарәләрен; гомумадм., исәп-стат., хезмәтне саклау, тариф-нормалаштыру, мобилизацияләү-бүлү, хезмәт базары, финанс-хисап, планлаштыру-икътисад (1930 дан) бүлекләрен; хезмәт бюросын (1927 дән); эшчеләр торакларын кооператив төзүгә булышлык итү ком-тын (1924 тән) үз эченә ала. Кантон (1930 га кадәр), район, шәһәр хезмәт бүлекләре б-н җитәкчелек итә. ТАССР ҮБКна, ТАССР ХКСна һәм РСФСРның шундый ук Халык комис-тына буйсына. СССР ҮБК, ХКС һәм ВЦСПСның 1933 ел 23 июнь, СССР ХКС һәм ВЦСПСның 1933 ел 10 сентябрь карарлары, ТАССР ХКСның һәм Профсоюзлар Татарстан советының 1933 ел 14 октябрь карары б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары Профсоюзларның Татарстан советына, ТАССР ХКС каршындагы Дәүләт план комиссиясенә һәм җирле профсоюз органнарына тапшырыла.

Халык комиссарлары: А.И.Догадов (1920–21), В.И.Догадов (1921–25), Ш.С.Измайлов (1925 — 1928 нең февр.), Б.Н.Нургалиев (1928 нең февр. — нояб.), С.Н.Смолов (1928 нең нояб. — 1929), М.Г.Яһүдин (1929–32), А.Ш.Хөсәенов (1932–33).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ЭЧКЕ́ СӘҮДӘ́ ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**, к. *Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ЭЧКЕ́ ЭШЛӘ́Р ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**, к. *Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ЭШЧЕ́, КРӘСТИЯ́Н ҺӘМ КЫЗЫЛА́РМИЯЧЕ ДЕПУТАТЛАРЫ́ СОВЕТЛАРЫНЫ́Ң ҮЗӘ́К БАШКАРМА́ КОМИТЕТЫ́** (ТАССР ҮБК), ТАССРның 1920–38 елларда *Татарстан АССР Советлары съездлары* арасында закон чыгару, бүлү һәм контрольдә тоту эшләрен башкаручы югары дәүләт хакимияте органы. ТАССР Совет съезды тарафыннан сайлана, аңа һәм Бөтенроссия ҮБКна буйсына. Иң элек 59 әгъзадан, 1921 дән — 71 әгъза һәм 21 әгъзалыкка кандидаттан, 1922 дән — 75 әгъза һәм 44 әгъзалыкка кандидаттан, 1923 тән — 75 әгъза һәм 45 әгъзалыкка кандидаттан, 1925 тән — 112 әгъза һәм 45 әгъзалыкка кандидаттан, 1926 дан — 116 әгъза һәм 55 әгъзалыкка кандидаттан, 1927 дән — 137 әгъза һәм 61 әгъзалыкка кандидаттан, 1929 дан — 143 әгъза һәм 55 әгъзалыкка кандидаттан, 1931 дән — 155 әгъза һәм 30 әгъзалыкка кандидаттан, 1934 тән 120 әгъзадан һәм 47 әгъзалыкка кандидаттан тора. ТАССР ҮБК респ-ка советлары съездының аерым вәкаләтләреннән тыш, аның барлык вазифаларын диярлек башкара. Ул ҮБК Президиумының, ТАССР хөкүмәтенең һәм совет хакимиятенең барлык органнары эшчәнлегенең гомуми юнәлешен билгели, законнар чыгару һәм идарә итү буенча эшләрне гомумиләштерә һәм килештерә, Совет Конституциясе, ТАССР Советлары съездлары һәм РСФСР һәм СССР үзәк органнары карарларының үтәлешен контрольдә тота. ТАССР ҮБК вәкаләтләре: респ-каның халык хуҗалыгы һәм эчке сәясәтенә гомуми җитәкчелек итү; гомуми адм. бүленеш һәм Татарстан чикләрендәге үзгәрешләр проектларын раслау; милли мәсьәләдә директивалар (күрсәтмәләр) билгеләү (РСФСР һәм СССР сәясәтенең гомуми юнәлеше б-н килешенгән булуы шарт); халык хуҗалыгы һәм аерым тармаклар үсешенең респ-ка планын билгеләү; респ-ка бюджетын раслау (РСФСР бюджеты өлеше буларак); җирле салымнар, җыемнар, салымнардан җыелучы керемнәрне һәм заёмнарны билгеләү; дәүләт һәм җирле керемнәрне, чыгымнарны контрольдә тоту; амнистия хокукы бирү (Бөтенроссия ҮБК хуплаганнан соң); законнарны бозучы җирле Советлар карарларын гамәлдән чыгару; РСФСР һәм СССР карамагындагы мәсьәләләр буенча законнар чыгару инициативасы хокукы; ТАССР терр-ясендәге барлык пр-тиеләр һәм оешмаларны (гамәлдәге армия учреждениеләреннән тыш) күзәтчелек итү һәм тикшерү һ.б. Ул ш.у. ТАССР ҮБК Президиумын сайлый, даими һәм вакытлы комиссияләр, ТАССР Хөкүмәте — ХКС оештыра, аның составын, халык комиссарларын билгели һәм эшләреннән азат итә, Бөтенроссия ҮБК Президиумы карамагындагы ТАССР вәкилләрен билгели. Сессия тәртибендә эшли. Сессияләр елга 3–6 тапкыр чакырылырга тиеш була, аларның һәркайсы, кагыйдә буларак, берничә көн дәвам итә. ТАССР ҮБК каршында татар телен гамәлгә кертү, адм., балалар тормышын яхшырту, совет учреждениеләре штатларын кыскарту, ачларга, авыруларга һәм яралы кызылармиячеләргә, демобилизацияләнгән кызылармиячеләргә ярдәм итү, реквизиция, җир, а.х.на булышу, торак, шефлык, пролетар студентлар көнкүрешен яхшырту, галимнәргә булышлык итү, В.И.Ленин исем. Тәрбиячесез калган балаларга ярдәм итү фондын оештыру һәм идарә итү, хатын-кызларның көнкүрешен һәм хезмәт шартларын яхшырту, дин эшләре, дәүләт кредиты һәм саклык-туплау эшләренә булышлык итү һ.б. комиссияләр эшли. ТАССР ҮБКның төп актлары: карарлар, резолюцияләр, нигезләмәләр. ТАССР ҮБК чакырылышлары: 1 нче (1920–21), 2 нче (1921–22), 3 нче (1922–23), 4 нче (1923–25), 5 нче (1925–26), 6 нчы (1926–27), 7 нче (1927–29), 8 нче (1929–31), 9 нчы (1931–34), 10 нчы (1934–38).

Респ-каның ҮБК Президиумы ТАССР ҮБК сессияләре арасындагы чорда югары дәүләт хакимияте органы вазифаларын үтәүче даими эшләүче орган була. Респ-ка советлары съездлары һәм ҮБК карарларының үтәлешенә күзәтчелек итә; совет органнарының урыннардагы эшләрен тикшерә; ТАССР ХКС һәм аерым халык комис-тлары, җирле советлар һәм аларның башкарма ком-тларының карарларын туктатып тора яки гамәлдән чыгара; респ-ка хөкүмәте тәкъдиме буенча ТАССР халык комиссарларын билгели һәм аларны эшләреннән азат итә; ХКС, халык комис-тлары һәм респ-каның башка учреждениеләре докладларын тыңлый; ТАССРның адм.-терр. бүленешен үзгәртә (Бөтенроссия ҮБКның раславы нигезендә); советлар съездларын һәм ТАССР ҮБК сессияләрен әзерли һәм аларны алып баруга кагылышлы башка мәсьәләләрне хәл итә. Карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара. ТАССР ҮБКның һәр чакырылышының 1 нче сессиясендә составы — Рәис, аның урынбасары (1922–25 тә — ике урынбасар), ТАССР ҮБК секретаре, Президиум әгъзалары һәм әгъзалыкка кандидатлар сайлана. ТАССР ҮБК Президиумы иң элек 7 әгъзадан, 1922 дән — 9 әгъза һәм 5 әгъзалыкка кандидаттан, 1924 тән — 11 әгъза һәм 3 әгъзалыкка кандидаттан, 1925 тән — 13 әгъза һәм 5 әгъзалыкка кандидаттан, 1926 дан — 15 әгъза һәм 6 әгъзалыкка кандидаттан, 1927 дән — 19 әгъза һәм 8 әгъзалыкка кандидаттан, 1929 дан — 15 әгъза һәм 7 әгъзалыкка кандидаттан, 1931 дән — 15 әгъза һәм 5 әгъзалыкка кандидаттан, 1934 тән 11 әгъза һәм 3 әгъзалыкка кандидаттан тора.

Респ-ка ҮБК Рәисе ТАССР ҮБК Президиумы исеменнән аңа билгеләнгән вәкаләтләргә таянып эшли, ҮБК сессияләрендә утырышларга җитәкчелек итә, РСФСР һәм СССРның үзәк учреждениеләрендә һәм урыннарда аерым мәсьәләләрне ачыклый һәм хәл итә; респ-ка закон актларын, ш.у. башка документларны раслый һ.б. Аның күрсәтмәләре Татарстандагы барлык учреждениеләр өчен мәҗбүри була.

ТАССР ҮБКның 1 нче чакырылышы 1920 нең 27 сентябрендә 59 кеше составында сайлана.

Беренче пленар утырышта (1920 нең 28 сент.) ТАССР ҮБК Рәисе (Б.Х.Мансуров), 7 кешедән торган ТАССР ҮБК Президиумы сайлана; 15 кешедән ТАССР хөкүмәте — ХКС (рәисе С.С.Сәетгалиев) оештырыла; амнистия проекты, изелгән Шәрекъ халыкларына мөрәҗәгать раслана; ТАССР ҮБКның эш регламенты кабул ителә.

1 нче сессиядә (1920 нең 2–3 дек.) ТАССР ХКС, ТАССР ХХС, Татарстан азык-төлек киңәшмәсе эшчәнлеге турындагы хисаплар раслана; ТАССР ҮБК турында Нигезләмә; РСФСРның халыкара эчке һәм хәрби торышы турында, орлык кампаниясе оештыру турында карарлар кабул ителә; Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советларының 8 нче Бөтенроссия съездына делегатлар сайлана.

2 нче сессиядә (1921 нең 1–2 марты) ТАССР ҮБК Президиумы, ТАССР Мәгариф халык комис-ты, Арча, Буа, Мамадыш башкарма ком-тлары, Зөя һәм Тәтеш кантоннары Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советлары эшчәнлеге турындагы хисаплар раслана; ТАССРда сәнәгать тармагын үстерү буенча чаралар күрү турында, ач крәстияннәрне башка җиргә күчерү турында, волость һәм авыл советлары, кантон советлары съездларына һәм ТАССР Советларының 2 нче съездына кабаттан сайлауларны күчерү турында карарлар кабул ителә; ТАССР ҮБК Президиумы составына үзгәрешләр кертелә.

3 нче сессиядә (1921 нең 21–22 мае) ТАССР ҮБК, ТАССР ХКС, Татарстан чәчү ком-ты, ТАССР Игенчелек халык комис-ты эшчәнлеге турындагы хисаплар раслана; азык-төлек ресурслары; азык-төлек салымы; кооперация һәм товар фонды оештыру турында, ТАССРның адм. һәм хуҗалык бүленеше турында, совет учреждениеләрендә штатлар кыскару турында карарлар кабул ителә.

ТАССР ҮБКның 2 нче чакырылышы 1921 нең 28 июнендә 71 әгъза һәм 21 әгъзалыкка кандидат составында сайлана.

1 нче сессиядә (1921 нең 29 июне) ТАССР ҮБК Рәисе (Р.Ә.Сабиров), 7 кешедән торган ТАССР ҮБК Президиумы сайлана; 15 кешедән ТАССР хөкүмәте — ХКС (рәисе К.Г.Мохтаров) оештырыла.

2 нче сессиядә (1921 нең 29–30 нояб.) ТАССР ХКС, Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларының Чистай кантон советы башкарма ком-ты эшчәнлеге турындагы хисаплар раслана; көзге уңыш нәтиҗәләре һәм язгы чәчү кампаниясе планы турында карарлар кабул ителә.

3 нче сессиядә (1922 нең 24–27 февр.) Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларының Бөгелмә кантон советы башкарма ком-ты эшчәнлеге турында хисап раслана; халыкара вазгыять һәм Генуя конференциясе турында; ачларга ярдәм итү турында; Халыкара ачларга ярдәм итү эшчеләр ком-ты эше турында, ТАССРда сәнәгать торышы турында, ТАССРда финанс торышы турында, а.х.һәм чәчү кампаниясе торышы турында, ТАССРда шәһәр шартларында кооперацияләр эше турында, советлар һәм башкарма ком-тлар вәкаләтләре срогы турында карарлар; ачлык вакытында чыдамлылык һәм түземлелек күрсәтергә өндәп ТАССР халкына; уңыш җыю буенча нәтиҗәсе булган губерна эшчеләренә, крәстияннәренә һәм гражданнарына; су һәм тимер юл транспорты хезмәткәрләренә мөрәҗәгатьләр кабул ителә; совет учреждениеләрендә штатлар кыскартылу турындагы хәбәр хуплана.

4 нче сессиядә (1922 нең 25–29 июне) Татарстан АССР оештырылуның 2 еллыгы турында доклад тыңлана; Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларының Зөя кантон советы башкарма ком-тының эшчәнлеге турында хисап раслана; 1922/23 уку елына халык мәгарифенең эш планы турында, яңа икътисади сәясәт (нэп) шартларында дәвалау-санитария эшләре торышы турында, салым сәясәте турында, терлекчелекне үстерү перспективасы, революцион закончалык турында, чәчү кампаниясе нәтиҗәләре турында карарлар кабул ителә; ТАССРдагы ачлык б-н бәйле рәвештә РСФСР хезмәт ияләренә мөрәҗәгать хуплана.

ТАССР ҮБКның 3 нче чакырылышы 1922 нең 10 декабрендә 75 әгъза һәм 44 әгъзалыкка кандидат составында сайлана.

1 нче сессиядә (1922 нең 10 дек.) ТАССР ҮБК Рәисе (Р.Ә.Сабиров), 9 әгъзадан һәм 5 әгъзага кандидаттан торган ТАССР ҮБК Президиумы сайлана; 13 кешедән ТАССР хөкүмәте — ХКС (рәисе К.Г.Мохтаров) оештырыла.

2 нче сессиядә (1923 нең 25–26 марты) кантон Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советлары башкарма ком-тларын үзгәртеп кору турында, ТАССРда сәнәгать торышы турында, җирле бюджет турында, чәчү кампаниясе һәм җир, а.х.сәясәтенең төп моментлары турында, ачлык б-н көрәш турында карарлар кабул ителә.

3 нче сессиядә (1923 нең 21–24 июле) Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларының Минзәлә кантон советы башкарма ком-ты эшчәнлеге турында хисап раслана; ТАССРда бердәм а.х. салымы кертү турында, ТАССРда сәнәгать торышы турында, чәчү кампаниясе нәтиҗәләре турында, ТАССРда коммуналь хуҗалык торышы турында карарлар кабул ителә; ТАССР ҮБК һәм аның Президиумы составына үзгәрешләр кертелә.

ТАССР ҮБКның 4 нче чакырылышы 1923 нең 24 декабрендә 75 әгъза һәм 45 әгъзалыкка кандидат составында сайлана.

1 нче сессиядә (1923 нең 26 дек.) ТАССР ҮБК Рәисе (Р.Ә.Сабиров), 9 әгъзадан һәм 5 әгъзалыкка кандидаттан торган ТАССР ҮБК Президиумы сайлана; 16 кешедән ТАССР хөкүмәте — ХКС (рәисе К.Г.Мохтаров) оештырыла; ТАССР Советларының 4 съездында тыңланган ТАССРда сәнәгать һәм сәүдә торышы турындагы доклад буенча резолюция раслана.

2 нче сессиядә (1924 нең 15–18 июне) финанс һәм җирле бюджет торышы турында, татар телен гамәлгә кертү эшләре нәтиҗәләре һәм киләсе елларга перспективалар турында, ТАССРда а.х.торышы һәм чәчү кампаниясе нәтиҗәләре турында, кулланучылар кооперациясе торышы турында карарлар кабул ителә; ТАССР ҮБК турындагы Нигезләмә раслана; ТАССР ҮБК Президиумы һәм ТАССР ХКС составына үзгәрешләр кертелә.

ТАССР ҮБКның 5 нче чакырылышы 1925 нең 9 гыйнварында 112 әгъза һәм 45 әгъзалыкка кандидат составында сайлана.

1 нче сессиядә (1925 нең 9 гыйнв.) ТАССР ҮБК Рәисе (Ш.Ш.Шәймәрданов), 13 әгъзадан һәм 5 әгъзалыкка кандидаттан торган ТАССР ҮБК Президиумы сайлана; 19 кешедән ТАССР хөкүмәте — ХКС (рәисе Х.З.Габидуллин) оештырыла; ТАССР Советларының 5 нче съездында тыңланган ТАССРда финанс һәм бюджет торышы турындагы доклад буенча резолюция раслана.

2 нче сессиядә (1925 нең 23–27 июне) ТАССР ХКС, ТАССР Игенчелек халык комис-ты, Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларының Тәтеш кантоны, Олы Шәмәк волосте һәм Алабирде советларының эшчәнлеге турында хисаплар; ТАССР ҮБК Президиумы карарлары раслана; ТАССР Конституциясе проекты, амнистия турында карар; Татарстанның барлык хезмәт ияләренә мөрәҗәгать кабул ителә; ТАССР ҮБК Президиумы һәм ТАССР ХКС составына үзгәрешләр кертелә.

3 нче сессиядә (1925 нең 3–5 дек.) ТАССР Мәгариф халык комис-ты, ТАССР ХКС каршындагы Коммуналь хуҗалык идарәсе эшчәнлеге турында хисаплар раслана; ТАССР халык комис-тлары турында гомуми нигезләмә, җирле бюджет турында карар кабул ителә; Советларга кабаттан сайлау кампаниясе буенча әзерлек чаралары турында хәбәр тыңлана.

ТАССР ҮБКның 6 нчы чакырылышы 1926 ның 14 мартында 116 әгъза һәм 55 әгъзалыкка кандидат составында сайлана.

1 нче сессиядә (1926 ның 14 марты) ТАССР ҮБК Рәисе (Ш.Ш.Шәймәрданов), 15 әгъзадан һәм 6 әгъзалыкка кандидаттан торган ТАССР ҮБК Президиумы сайлана; 19 кешедән ТАССР хөкүмәте — ХКС (рәисе Х.З.Габидуллин) оештырыла.

2 нче сессиядә (1926 ның 10–17 сент.) ТАССР ҮБКның оештыру бүлеге, Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларының Бөгелмә кантоны советының башкарма ком-ты эшчәнлекләре турында хисаплар, ТАССР ҮБК Президиумы карарлары раслана; ТАССР ХКС турында Нигезләмә; гомум башлангыч белем бирүне кертү һәм мәктәп төзелеше турында, 5 елга ТАССРда а.х.н үстерү һәм алга җибәрү перспективалары турында, ТАССРда сәнәгать торышы һәм 1926–27 гә аның перспективалары турында, 1926–27 гә җирле бюджет төзү перспективалары турында, экономия режимы турында карарлар кабул ителә; ТАССР ҮБК турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертелә; гомумбелем бирүне кертү б-н бәйле рәвештә ТАССР хезмәт ияләренә мөрәҗәгать хуплана.

3 нче сессиядә (1927 нең 12–13 марты) татар телен гамәлгә кертү эше һәм киләсе елларга перспективалар нигезләмәсе турында, ТАССРның адм. бүленеше һәм төзелешендә-

ге (районлаштыру турында) өлешчә үзгәрешләр турында карарлар кабул итәлә; ТАССР ХКС составына үзгәрешләр кертелә.

ТАССР ҮБКның 7 нче чакырылышы 1927 нең 21 мартында 137 әгъза һәм 61 әгъзалыкка кандидат составында сайлана.

1 нче сессиядә (1927 нең 22 марты) ТАССР ҮБК Рәисе (М.Ә.Әхмәтшин), 19 әгъзадан һәм 8 әгъзалыкка кандидаттан торган ТАССР ҮБК Президиумы сайлана; 17 кешедән ТАССР хөкүмәте — ХКС (рәисе Ш.Ш.Шәймәрданов) оештырыла.

2 нче сессиядә (1927 нең 4–8 июле) ТАССР Юстиция халык комис-ты, Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларының Буа кантон башкарма ком-ты эшчәнлеге турында хисаплар раслана; ТАССР ҮБК турында Нигезләмә һәм ТАССР ҮБК Президиумы эше турында таләпләр; ТАССР халык хуҗалыгын үстерү һәм реконструкцияләүнең 15 еллык планы турында, а.х.н күмәкләштерү һәм интенсивлаштыру буенча чаралар турында карарлар кабул итәлә; ТАССР ҮБК һәм аның Президиумы, ТАССР ХКС составына үзгәрешләр кертелә.

3 нче сессиядә (1927 нең 20–21 сент.) 1927/28 елга җирле бюджет раслана; ТАССРның барлык хезмәт ияләренә мөрәҗәгать кабул итәлә; ТАССР ҮБК һәм аның Президиумы, ТАССР ХКС составына үзгәрешләр кертелә.

4 нче сессия (1928 нең 12–14 февр.) а.х. продуктларын әзерләү һәм халыкны сәнәгый товарлар б-н тәэмин итү турында, башлангыч совет аппараты һәм аның алдагы бурычлары турында, ТАССР ҮБК Президиумы карарлары кабул итәлә; ТАССР ҮБК һәм аның Президиумы, ХКС составына үзгәрешләр кертелә.

5 нче сессиядә (1928 нең 3–6 окт.) ТАССРда терлекчелек тармагының торышы һәм аның үсеш перспективалары турында, үзара салым турында; ТАССР крәстияннәрнең үзара ярдәмләшү оешмалары ҮК эшчәнлеге һәм эш перспективалары турында, 1929да Советларга яңадан сайлаулар турында, ТАССРның адм.-терр. берәмлекләре кысаларындагы үзгәрешләр турында карарлар кабул итәлә; ТАССР ҮБК һәм Президиумы составына, ТАССР ХКС төзелешенә һәм составына үзгәрешләр кертелә.

ТАССР ҮБКның 8 нче чакырылышы 1929 ның 8 маенда 143 әгъза һәм 55 әгъзалыкка кандидат составында сайлана.

1 нче сессиядә (1929 ның 8 мае) ТАССР ҮБКның Рәисе (Х.И.Моратхуҗин), 15 әгъзадан һәм 7 әгъзалыкка кандидаттан торган ТАССР ҮБК Президиумы сайлана; 18 кешедән ТАССР хөкүмәте — ХКС (рәисе К.Х.Исмаев) оештырыла.

2 нче сессиядә (1929 ның 10–15 дек.) ТАССРда мәдәни төзелеш һәм халык хуҗалыгы үсешенең бишьеллык планы; 1929/30 елларга ТАССР бюджеты раслана; ТАССРда күмәкләштерүнең торышы һәм алда торган бурычлары турында, советларның массакүләм эше турында, ТАССРда районнарга бүлү (районлаштыру) турында карарлар кабул итәлә; ТАССР ҮБК һәм аның Президиумы, ТАССР ХКС составына үзгәрешләр кертелә.

3 нче сессиядә (1930 ның 24–26 июле) Татарстан АССРның 10 еллыгына багышланган доклад тыңлана; Беренче Казан укчылар дивизиясен шефлыкка алу турында карар кабул итәлә; ТАССР ҮБК Президиумы карарлары раслана; ТАССР ҮБК һәм аның Президиумы, ТАССР ХКС составына үзгәрешләр кертелә.

ТАССР ҮБКның 9 нчы чакырылышы 1931 нең 23 февралендә 155 әгъза һәм 30 әгъзалыкка кандидат составында сайлана.

1 нче сессиядә (1931 нең 23 февр.) ТАССР ҮБК Рәисе (Х.И.Моратхуҗин), 15 әгъзадан һәм 5 әгъзалыкка кандидаттан торган ТАССР ҮБК Президиумы сайлана; 16 кешедән ТАССР хөкүмәте — ХКС (рәисе К.А.Абрамов) оештырыла.

2 нче сессиядә (1932 нең 20–23 марты) 1932 гә ТАССРның халык-хуҗалык планы; 1932 гә ТАССР бюджеты; ТАССР ҮБК Президиумы карарлары раслана; язгы а.х. кампаниясенә әзерлек турында, башлангыч һәм урта мәктәп турында, язгы чәчүгә әзерлек төгәлләнүнең бөтентатар эстафетасы турында карарлар кабул итәлә; ТАССР ҮБК һәм аның Президиумы составына, ТАССР ХКС төзелешенә һәм составына үзгәрешләр кертелә.

3 нче сессиядә (1932 нең 26–29 дек.) беренче соц. бишьеллыкка нәтиҗәләр ясала; 1933 елга ТАССРның халык хуҗалык планы; ТАССР ҮБК Президиумы карарлары раслана; советларның оештыру-массакүләм эшләре торышы һәм 1933 кә бурычлары турында, агротехник уку һәм наданлыкны бетерү турында карарлар кабул итәлә; ТАССР ҮБК һәм аның Президиумы, ТАССР ХКС составына үзгәрешләр кертелә.

4 нче сессиядә (1934 нең 15–19 марты) 1934 кә ТАССРның халык хуҗалыгы планы; 1934 кә ТАССР бюджеты һәм 1933 елда ТАССР бюджеты үтәлеше турында хисап; ТАССР ҮБК Президиумы карарлары раслана; ТАССР советларының оештыру-массакүләм эшләре турында, 1934 тә язгы чәчүгә әзерлек турында карарлар; барлык авыл советларына, сельполарга һәм колхозларга, колхозчыларга, ялгыз хезмәт ияләренә, совет һәм кооп. активына мөрәҗәгать кабул итәлә; ТАССР ҮБК һәм аның Президиумы составына үзгәрешләр кертелә.

ТАССР ҮБКның 10 нчы чакырылышы 1934 нең 29 декабрендә 120 әгъза һәм 47 әгъзалыкка кандидат составында сайлана.

1 нче сессиядә (1934 нең 29 дек.) ТАССР ҮБК Рәисе (Г.Г.Байчурин), 11 әгъзадан һәм 3 әгъзалыкка кандидаттан торган ТАССР ҮБК Президиумы сайлана; 12 кешедән ТАССР хөкүмәте — ХКС (рәисе К.А.Абрамов) оештырыла.

2 нче сессиядә (1935 нең 25–28 июне) Татарстан АССР оештырылуның 15 еллыгына багышланган доклад тыңлана; 1935 кә ТАССР бюджеты раслана; Татарстан халкына мөрәҗәгать кабул итәлә.

3 нче сессиядә (1936 ның 9–15 марты) 1936 га ТАССРда мәдәни төзелеш һәм халык хуҗалыгын үстерү планы; 1936 га ТАССР бюджеты һәм 1935 тә ТАССРда респ-ка һәм җирле бюджет үтәлеше турында хисап җыентыгы; ТАССР ҮБК Президиумы карарлары раслана; ТАССРда белемсез һәм аз белемлеләрне укыту буенча эш турында карар кабул итәлә; ТАССР ҮБК һәм Президиумы, ТАССР ХКС составына үзгәрешләр кертелә.

4 нче сессиядә (1936 ның 1 июле) СССР Конституциясе проекты хуплана; ТАССР Конституциясен эшләү өчен Конституция комиссиясе сайлана; ТАССР ҮБК Президиумы карарлары раслана; заём турында, ТАССР советларының чираттан тыш съезды һәм район советлары съездлары чакырылышы турында карарлар кабул итәлә; орденлы Татарстанның барлык хезмәт ияләренә мөрәҗәгате хуплана; 1936 га ТАССР респ-ка һәм җирле бюджетына, ТАССР ХКС составына үзгәрешләр кертелә.

5 нче сессиядә (1937 нең 27–29 марты) 1937 гә ТАССР респ-ка бюджеты һәм 1936 да ТАССР бюджеты үтәлеше турында хисап; ТАССР ҮБК Президиумы карарлары раслана; ТАССР ҮБК һәм аның Президиумы составына, ТАССР ХКС төзелешенә һәм составына үзгәрешләр кертелә; ТАССР Баш мәхкәмәсе оештырыла.

6 нчы сессиядә (1937 нең 26 июне) 1937 гә ТАССР җирле бюджетлары; ТАССР ҮБК Президиумы карарлары раслана; ТАССР ҮБК һәм аның Президиумы составына, ТАССР ХКС төзелешенә һәм составына үзгәрешләр кертелә.

7 нче сессиядә (1937 нең 16 сент.) ТАССР ҮБК Президиумы карарлары раслана; ТАССР ҮБК һәм аның Президиумы, ТАССР ХКС составына үзгәрешләр кертелә.

8 нче сессиядә (1938 нең 25–26 февр.) ТАССР ЮСна сайлаулар турында Нигезләмә; ТАССР ҮБК Президиумы карарлары раслана; ТАССР ҮБК һәм аның Президиумы составына, ТАССР ХКС төзелешенә һәм составына үзгәрешләр кертелә; ТАССР ҮБК гамәлдән чыгу сәбәпле, эшләрен кабул итү акты хуплана.

1937 дә ТАССР Конституциясен кабул итү б-н, 1938 дә ТАССР ҮБК гамәлдән чыгарыла, аның вазифалары ТАССР ЮСна (к. *Татарстан Республикасы Югары Советы*) һәм *Татарстан АССР Халык Комиссарлары советына* тапшырыла.

ТАССР ҮБК Рәисләре: Б.Х.Мансуров (1920–21), Р.Ә.Сабиров (1921–25), Ш.Ш.Шәймәрданов (1925–27), М.Ә.Әхмәтшин (1927–29), Х.И.Моратхуҗин (1929–32), М.Г.Яһүдин (1932–34), Г.Г.Байчурин (1934–37), Г.А.Динмөхәммәтов (1937–38).

Чыг.: Образование и государственно-правовое положение Татарской АССР: Сб. док. и материалов. К., 1960. Ч. 1.

*Әд.:* Хафизов Ш.Ш. Развитие советской государственности татарского народа. К., 1966; Каримов А.М. Съезды Советов Татарии (1920–1937 гг.). К., 1967. *Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ЭШЧЕ́-КРӘСТИЯННӘ́Р ИНСПЕ́КЦИЯСЕ ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**. Тарихы Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы Казан губерна башкарма ком-тының 1918 ел 15 октябрь карары нигезендә губерна башкар-

ма ком-ты дәүләт контроле бүлеге оештырылудан башлана. Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы Казан губерна башкарма ком-тының 1919 ел 20 гыйнвар карары һәм Бөтенроссия ҮБКның 1919 ел 9 апрель Декреты б-н РСФСР Дәүләт контроленең Казан губерна бүлекчәсе итеп үзгәртелә, РКП(б) Казан губерна ком-ты бюросының 1920 ел 19 февраль һәм Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы Казан губерна башкарма ком-тының 1920 ел 20 февраль карарлары б-н исеме губерна башкарма ком-тының эшче-крәстияннәр инспекциясе бүлеге дип алыштырыла, Бөтенроссия ҮБК һәм РСФСР ХКСның 1920 ел 27 май Декреты һәм ТАССР ҮБКның 1920 ел 28 сентябрь карары б-н ТАССР Э.-к.и.х.к. итеп үзгәртелә. Дәүләт аппараты эшен өйрәнү һәм аны камилләштерү чараларын эшләү, хуҗалык һәм дәүләт идарәсенең аерым тармакларында тикшерүләр алып бару, совет учреждениеләрендә бюрократлыкка һәм чуалчыклыкка каршы көрәш, эшчеләрне һәм крәстияннәрне җитәкче вазифаларга әзерләү, югары закон чыгаручы органнар карарларының үтәлешен күзәтү б-н шөгыльләнә. Халык комис-тының вәкаләтләре респ-каның барлык учреждениеләрен һәм ведомстволарын колачлый. Ул җирле дәүләт һәм кооперация оешмаларында һәм пр-тиеләрендә, акц. җәмгыятьләрендә һәм концессияләрдә инспекция-ревизия тикшерүләре уздыруга, дәүләт учреждениеләренә, пр-тиеләренә һәм оешмаларына кимчелекләрне бетерү, структураны үзгәртү, вазифаи затларны эштән читләштерү һәм дисциплинар җәзага тарту турында күрсәтмәләр бирүгә, аерым ялгышлары һәм җинаятьләре өчен җитәкче хезмәткәрләргә карата адм. һәм мәхкәмә эше кузгатуга, ревизия тикшерүендәге учреждениеләрнең һәм вазифаи затларның (югары хакимият һәм идарә органнары, мәхкәмә һәм прокуратурадан тыш) законсыз боерыкларын һәм гамәлләрен туктатып торуга, хезмәтне фәнни нигездә оештыру мәсьәләләрен карау өчен съездлар, конференцияләр һәм киңәшмәләр чакыруга хокуклы була. Гомуми, техник-сәнәгать, хәрби, финанс, а.х. (1921 дән), адм. (1922 дән), ревизия (1923 тән), дәүләт аппаратын камилләштерү (1923 тән) бүлекләрен, шикаятьләр бюросын (1922 дән) үз эченә ала. 1927 дән ТАССР Э.-к.и.х.к.ның хокуклары киңәйтелә: штатлар, органнарның структур өлешләрен кыскарту, вазифаи затларны дисциплинар җәзага тарту, читләштерү һәм эштән азат итү мәсьәләләрендә Халык комис-тының карарлары барлык дәүләт учреждениеләре һәм пр-тиеләре өчен үтәлергә тиешле соңгы һәм зарури чара булып исәпләнә. 1930 еллар башында ТАССР Э.-к.и.х.к. составына эшләр башкару идарәсе, оештыру-масса, финанс бүлекләре, сәнәгать, сыйфат күрсәткечләре һәм техникадан файдалану, транспорт, төзелеш, совхозларны, колхозларны һәм МТСларны ныгыту, уңышны күтәрү һәм югалтулар б-н көрәш, сәүдә-кооперация, җәмәгать тукланы, советлар, үтәлешне контрольдә тоту һәм тикшерү, дәүләт аппаратын һәм соц. милекне саклауны яхшырту һәм арзанайту, социаль-мәдәни мәсьәләләр төркемнәре, бәяләргә дәүләт инспекциясе, шикаятьләр бюросы керә. ТАССР Э.-к.и.х.к.ның респ-ка кантоннары һәм районнарындагы вәкаләтле вәкилләре б-н җитәкчелек итә. ТАССР ҮБКна, ТАССР ХКСна һәм РСФСРның шундый ук Халык комис-тына буйсына. СССР ҮБК һәм ХКСның 1934 ел 11 февраль карары б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары СССР ХКС каршындагы Совет контроле комиссиясенең ТАССР буенча Вәкаләтле вәкиленә тапшырыла.

Халык комиссарлары: Г.С.Касыймов (1920–1921 нең июне), А.Г.Ганиев (1921 нең июнь-авг.), Х.А.Чанышев (1921 нең авг. — 1922), В.И.Исхаков (1922–23), А.В.Недачин (1923–25), И.М.Батанов (1925–26), Н.Ф.Новиков (1926–27), М.Ә.Әхмәтшин (1927–28), Г.Г.Ганиев (1928–30), Г.Г.Байчурин (1930–34).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ЮСТИ́ЦИЯ ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**, к. *Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н АССР ЯГУЛЫ́К СӘНӘГАТЕ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**. Тарихы 1915 ел 17 август Законы нигезендә Махсус киңәшмә рәисе каршында Казан губернасында ягулык буенча Вәкаләтле вәкил вазифасы булдырылудан башлана. 1917 ел 13 июнь нигезләмәсе буенча аның вазифалары Казан губерна ягулык ком-тына тапшырыла. Ком-т Крәстиян депутатлары Казан губерна советы башкарма ком-тының 1918 ел 14 май карары б-н — Крәстиян депутатлары губерна советының вак кредит кассасы каршындагы тәэминат бүлеге, Казан губерна ХХСның 1918 ел 13 июль карары б-н — губерна ХХС каршындагы ягулык бүлеге, Казан губерна ХХС Президиумының 1919 ел 29 гыйнвар карары б-н — Казан губерна ягулык ком-ты, БҮБК һәм РСФСР ХХСның 1920 ел 25 июнь Декреты б-н — ТАССР ХХСның ягулык бүлеге, ТАССР ХХС Президиумының 1921 ел 17 июнь карары б-н — ТАССР ХХСның Баш ягулык идарәсе, ТАССР ХХС Президиумының 1922 ел 21 июнь һәм ТАССР ХКС Икътисади киңәшмәсенең (ЭКОСО) 1922 ел 14 июль карарлары б-н — ТАССР Берләштерелгән урман һәм агач эшкәртү сәнәгатенең ягулык бүлеге, ТАССР ХКСның 1932 ел 29 апрель карары б-н — ТАССР ХКС каршындагы Ягулык ком-ты (ТАССР ХКСның 1936 ел 22 апр. карары б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары ТАССР ХКС каршындагы Дәүләт план комиссиясенә, ТАССР Җирле сәнәгать халык комис-тына һәм ТАССР Коммуналь хуҗалык халык комис-тына тапшырыла), ТАССР ЮС Президиумының 1939 ел 17 декабрь һәм 1943 ел 18 гыйнвар Указлары б-н — ТАССР ХКС (1946 дан — МС) каршындагы Җирле ягулык сәнәгате идарәсе, ТАССР ЮС Президиумының 1953 ел 26 май карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1953 ел 30 май Указы б-н — ТАССР Җирле һәм ягулык сәнәгате министрлыгы, ТАССР ЮС Президиумының 1954 ел 7 август карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1954 ел 16 август Указы б-н кабат ТАССР МС каршындагы Җирле ягулык сәнәгате идарәсе итеп үзгәртелә. Идарә ТАССР МСның 1959 ел 22 апрель карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1959 ел 14 май Указы б-н гамәлдән чыгарыла, вәкаләтләре ТАССР Җирле сәнәгать министрлыгына һәм Татарстан Урман хуҗалыгы һәм урманнарны саклау идарәсенә тапшырыла; ТАССР ЮС Президиумының 1965 ел 16 февраль карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1965 ел 24 февраль Указы б-н ТАССР МСның Җирле һәм ягулык сәнәгате идарәсе буларак торгызыла, ТАССР ЮС Президиумының 1966 ел 8 гыйнвар карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1966 ел 12 гыйнвар Указы б-н ТАССР Я.с.м. итеп үзгәртелә. Урман хәзерләү һәм чыгару, аннан такта продукциясе һәм агач эшләнмәләре җитештерүне, нефть чыгару һәм эшкәртүне оештыру, респ-ка халкын, пр-тиеләрен һәм учреждениеләрен ягулык б-н тәэмин итү б-н шөгыльләнә. Секретариатны, планлаштыру-икътисад, җитештерү-техник, кадрлар бүлекләрен, бухгалтерияне үз эченә ала. Әлек министрлык карамагында 2 урман сәнәгате хуҗалыгы, 2 сәнәгать комб-ты, 6 (1968 дән — 17) район һәм шәһәр ягулык сату оешмасы, 1980 елларда 5 пр-тие, 27 ягулык сату учреждениесе була. ТАССР МСна һәм РСФСРның шундый ук министрлыгына буйсына. ТАССР ЮС Президиумының 1988 ел 21 ноябрь Указы б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары Татарстан терр. «Татлестоппром» урман-ягулык ҖБгә тапшырыла.

Министрлар: М.Г.Ганиев (1966–83), М.К.Рәмиев (1983–88).

Ш.у.к. *Ягулык сәнәгате.*

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССРның҇ ҺӨНӘРИ́-ТЕ́ХНИК БЕЛЕ́М БИРУ́ ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**. СССР ХКС каршындагы Хезмәт резервлары баш идарәсенең 1940 ел 19 октябрь боерыгы нигезендә Татарстан хезмәт резервлары респ-ка идарәсе буларак оештырыла; РСФСР МС каршындагы Баш һөнәри-техник белем бирү идарәсенең 1959 ел 5 ноябрь боерыгы б-н Татарстан респ-ка һөнәри-техник белем бирү идарәсе итеп үзгәртелә, ТАССР ЮС Президиумының 1987 ел 4 февраль Указы б-н исеме ТАССР Һөнәри-техник белем бирү дәүләт ком-ты дип үзгәртелә. Һөнәри-техник белем бирү системасында яшьләрдән квалификацияле эшчеләр әзерләүне контрольдә тота һәм җитәкли, кадрларны производствода һөнәри өйрәтүгә методик ярдәм күрсәтә. Секретариатны, бухгалтерияны, планлаштыру, квалификацияле эшчеләрне әзерләү, исәпкә алу һәм урнаштыру, планлаштыру-җитештерү, шәһәр һөнәри-техник уч-щеләре, авыл һөнәри-техник уч-щеләре, урта һөнәри-техник уч-щеләр, укыту-методик, кадрлар, капиталь төзелеш бүлекләрен үз эченә ала. Дәүләт ком-тына шәһәр һәм авыл һөнәри-техник уч-щеләре (һөнәри уч-щеләр), Казан индустриаль-пед. һәм төзелеш, Бөгелмә индустриаль-пед. техникумнары буйсына. ТАССР МСна һәм РСФСРның шундый ук дәүләт ком-тына (1940–46 да — СССР ХКС каршындагы Хезмәт резервлары баш идарәсенә, 1946–53 тә — СССР Хезмәт резервлары министрлыгына,

1954–59 да СССР МС каршындагы Хезмәт резервлары баш идарәсенә, 1959–65 тә — РСФСР МС каршындагы Баш һөнәри-техник белем бирү идарәсенә) буйсына. ТАССР ЮС Президиумының 1988 ел 8 август Указы б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары ТАССР Халык мәгарифе министрлыгының Һөнәри-техник белем бирү идарәсенә тапшырыла.

Рәисе — А.А.Камалиев (1987–88).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССРны́ң АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́Н ҖИТЕШТЕРҮ́ ТЕ́ХНИКАСЫ БЕЛӘ́Н ТӘЭМИ́Н ИТҮ́ ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**. КПССның Татарстан өлкә ком-ты бюросы һәм ТАССР МСның 1961 ел 25 апрель карары нигезендә Татарстан респ-ка «Сельхозтехника» берләшмәсе (*«Татсельхозтехника»*) буларак оеша, ТАССР ЮС Президиумының 1978 ел 15 сентябрь Указы б-н ТАССР Авыл хуҗалыгын җитештерү техникасы б-н тәэмин итү дәүләт ком-ты итеп үзгәртелә. Колхозларның һәм совхозларның барлык төр техникага, минераль ашламаларга һ.б. матди-техник чараларга ихтыяҗын тәэмин итү, а.х. техникасын төзекләндерүне, аны файдалануда ярдәм күрсәтүне оештыру б-н җитәкчелек итә. Канцелярияне, секретариатны, бухгалтерияны, фермаларны механикалаштыру һәм аларга техник хезмәт күрсәтү, колхозларга һәм совхозларга производство хезмәте күрсәтү, автотранспорт, тәэминатны һәм склад хуҗалыгын оештыру, планлаштыру-икътисад, капиталь төзелеш, контроль-ревизия, социаль мәсьәләләр һәм кадрлар идарәләрен; ремонт һәм техник хезмәт күрсәтү, яңа техника, хезмәт һәм хезмәт хакы, финанс, ягулык һәм нефть хуҗалыгы, хезмәтне саклау бүлекләрен; әйләнә-тирәне саклау һәм табигый энергетика ресурсларын рациональ файдалану төркемен үз эченә ала. Дәүләт ком-ты системасына «Татсельхозтехника»ның 37 район берләшмәсе һәм 20 бүлекчәсе, 3 махсус кибет, 7 база, 3 авторемонт з-ды, үзәк хәзерләүләр остаханәсе, «Татсельхозкомплект» һәм проектлау-конструкторлык конторалары, «Татсельхозмонтаж» һәм «Мехтрест» трестлары керә. РСФСРның шундый ук дәүләт ком-тына (1978 гә кадәр — Бөтенроссия «Россельхозтехника» берләшмәсенә) һәм ТАССР МСна буйсына. ТАССР ЮС Президиумының 1985 ел 17 декабрь Указы б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары ТАССР Агросәнәгать комплексына тапшырыла.

Рәисе — Н.Г.Энвальд (1978–85).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АССРны́ң МАТДИ́-ТЕ́ХНИК ТӘЭМИНА́Т ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**. ТАССР МСның 1957 ел 20 август күрсәтмәсе нигезендә ТАССР МС каршындагы Тәэминат һәм сәүдә идарәсе буларак оештырыла, ТАССР ЮС Президиумының 1979 ел 23 октябрь Указы б-н ТАССР (1990 нан — ТССР) Матди-техник тәэминат дәүләт ком-ты итеп үзгәртелә. Дәүләт бюджет оешмаларын һәм пр-тиеләрен матди ресурслар б-н тәэмин итү буенча тәэминат-арадашчылык операцияләре башкара. Секретариатны, гомуми, планлаштыру-икътисад, финанс-бухгалтерлык, текстиль продукциясе, металл һәм металл эшләнмәләр, химия сәнәгате, төзелеш, ягулык-майлау материаллары һәм ягулык, җирле төзелеш материаллары, җиһазлар бүлекләрен үз эченә ала. Дәүләт ком-ты системасына Казан товарлар базасы һәм хуҗалык исәбендәге вак күмәртәләп сату кибетләре керә. РСФСРның шундый ук дәүләт ком-тына һәм ТАССР МСна буйсына. РСФСР Матди-техник тәэминат дәүләт ком-тының 1991 ел 14 июль боерыгы б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары Татарстан «Татгосснаб» коммерция-арадашчылык фирмасына тапшырыла.

Рәисләре: Х.С.Хәбибуллин (1979–84), Н.Ф.Козарь (1984–86), В.М.Хәбибуллин (1986–89), З.Ф.Сабиров (1989–91).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н АУЧЫЛА́Р ҺӘМ БАЛЫКЧЫЛА́Р КООПЕРАТИВЛАРЫ́ ӨЛКӘ́ БЕРЛЕГЕ́**, 1919 елның мартында Казанда оештырыла. Казан губернасында балык тоту һәм сунарчылык б-н көн күрүчеләр берлеге буларак барлыкка килә. 1920 дән шул исемдә. Максаты — респ-када аучылык һәм балык тоту эшен җайга салу. 1933 нең сентябрендә эшчәнлеге туктатыла.

**«ТАТАРСТА́Н БОЛЬШЕВИГЫ́»**, журнал; к. *«Коммунист Татарии»*.

**ТАТАРСТА́Н ГЕНЕРАЛЛАРЫ́ ҺӘМ АДМИРАЛЛАРЫ́ МУЗЕЕ́** (мәктәп музее), Казанда. 2009 елда оештырыла. Музей концепциясен эшләүдә И.А.Иванова, ТРның партизаннар һәм подпольщиклар советы рәисе Р.Д.Гәрәев һ.б. катнаша. Экспозиция мәйданы 56,3 *м*², 70 тән артык, ш.и. патша Россиясе генерал һәм адмираллары турында 20 дән артык мәгълүматны үз эченә ала. Төп экспозицияләр — Россиянең сугыш даны көннәре, 1941–45 тәге Бөек Ватан сугышында Татарстан генераллары һәм адмираллары, 19–21 йөзләрдә локаль конфликтларда катнашкан Татарстан генераллары һәм адмираллары, 1812 елгы Ватан сугышы вакытында рус армиясенең 1813–14 еллардагы чит ил яуларында катнашкан генераллары. Экспозициянең нигезен ТРның Казан губернасында туган югары хәрби состав офицерлары, ш.у. Бөек Ватан сугышында катнашучылар турында мәгълүмат тәшкил итә. Алар арасында беренче рус окольничие һәм Дума генералы А.А.Шепелев, 1812 дә Казан һәм Вятка ополчениеләре башлыгы, артиллерия генерал-майоры Д.А.Булыгин, Госманлылар дәүләте армиясе генералы М.М.Яваев (Шакир паша); Россия хәрби флотында татарлардан беренче вице-адмирал И.Д.Искәндәров, Советлар Союзы Геройлары маршал Л.А.Говоров, армия генераллары М.Ә.Гәрәев, В.В.Герасимов, генерал-лейтенант Г.Б.Сафиуллин, ш.у. генерал-майорлар Ә.Г.Юлашев, М.Р.Йосыпов, генерал-лейтенантлар Х.И.Камалов, Р.Г.Ризатдинов, С.Җ.Япиев, генерал-полковниклар Р.С.Акчурин, Э.Г.Вәлиев, М.Х.Колахмәтов һ.б. бар. Музей Татарстан Респ-касының Россия дәүләтчелеген ныгытуга булышлык итүче иҗтимагый оешмасы, ТР генераллары советы, сугыш һәм хәрби хезмәт ветераннары (инвалидлары) ком-ты б-н хезмәттәшлек итә; эзләнү эшләренә һәм яшьләрне хәрби-патриотик рухта тәрбияләүгә зур өлеш кертә.

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**ТАТАРСТА́Н ГЕОЛО́ГИК РАЗВЕ́ДКА ИДАРӘСЕ́**, «Татнефть» АҖ бүлеге, Казанда урнашкан. 1938 елда ТАССР геол. идарәсе буларак оештырыла, 1939 дан Татарстан геол. разведка тресты, 1951 дән «Татнефтегазразведка» (1986 да бетерелә). 1993 тә Казан геол. экспедиция, Геол. эзләнү конторасы һәм ТатНИПИнефтьнең Казан бүлеге җирлегендә Казан геол. разведка идарәсе оештырыла (1957 дән «Татнефть» структур бүлекчәсе). 1993 нең ахырыннан хәзерге исемендә. Т.г.р.и. Казан комплекслы геол. экспедицияне, «Проект», «Запаслар», «Геодинамика», «Нейросейсм», «Геофизик һәм геохимик алымнар», «Гидрология», «Эзләнү-разведка геологиясе» фәнни-җитештерү үзәкләрен; мәгълүматларны анализлау үзәген, региональ аналитик лаб-яне, бораулау эшләре цехын, җитештерү җиһазлары базасын берләштерә. Т.г.р.и. нефть, газ, битумнарны, җир асты суларын һәм руда булмаган файдалы казылмаларны разведкалау, аларның запасын исәпләү, геоэкология, геол. һәм гидрогеол. рәсемгә төшерү өлкәләрендә махсуслаша. Т.г.р.и. эчәргә яраклы минераль сулар җитештерү һәм сату хокукына ия. Идарә тарафыннан 100 дән артык, ш.и. Ромашкино һәм Яңа Елховой нефть чыганаклары ачыла һәм үзләштерелә, нефть запаслары, төзелеш материалларының 900 дән артык чыганагы исәпкә алына; Баулы, Зәй, Нурлат һ.б. шәһәрләр эчәргә яраклы су б-н тәэмин ителә. Ачыкланган һәм эшкәртелгән Чупай (дивар ташы), Бөгелмә (кирпеч балчыгы), Матюшино (известьташ) һ.б. чыганаклар җирлегендә тау эшләре пр-тиеләре төзелә һәм элек эшләгәннәре киңәйтелә.

Җитәкчеләре: М.Х.Маркарян (1939), Г.В.Ефименко (1940), М.П.Сметанин (1941), Б.М.Йосыпов (1942–44), А.П.Дмитриенко (1944–47), М.С.Голобоков (1947–57), А.Г.Эйгенсон (1957–67), М.Н.Хәйретдинов (1967–86), М.Н.Александров (1986), Н.С.*Гатиятуллин* (1993 тән).

**ТАТАРСТА́Н ДӘҮЛӘ́Т ГЕОЛО́ГИК РАЗВЕ́ДКА ТРЕСТЫ́**, к. *Татарстан геологик разведка идарәсе*.

**«ТАТАРСТА́Н» ДӘҮЛӘ́Т ТЕЛЕРАДИОТАПШЫРУЛА́Р КОМПА́НИЯСЕ** («Татарстан» ДТРК), Татарстан Респ-касында *телевидение тапшырулары* һәм *радиотапшырулар* алып баручы иҗади-сәнәгый оешма, ТР дәүләт идарәсе органы хокукларында эш итә. 1930 елда СССР Почта һәм телеграф халык комис-тының Казан радио үзәге һәм Радио советы буларак төзелә, 1932 дән — ТАССРның ҮБК Президиумы каршында Радиотапшырулар буенча Татарстан өлкә ком-ты, 1933 тән — ТАССР ХКС каршындагы Радиотапшырулар һәм радиолаштыру буенча Татарстан Респ-ка ком-ты, 1949 дан — ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар ком-ты, 1953 тән — ТАССР Мәдәният министрлыгының радиомәгълүмат бүлеге, 1958 дән — ТАССР МС каршындагы Радио-

тапшырулар һәм телевидение ком-ты, 1971 дән — ТАССР МСның Телевидение һәм радиотапшырулар ком-ты, 1982 дән — ТАССРның Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт ком-ты, 1990 нан — ТССРның Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт ком-ты, ТР Президентының 1992 ел 7 июль карары б-н — «Татарстан» ДТРК. Җитәкчеләре: С.Г.*Фәйзуллин*, Х.Хисмәтуллин, Н.Максудов, С.С.Касыймов, К.Ш.Шәфигуллин, С.Гыйльманшин, Г.Г.Батталов, Ф.Я.Рәхмәтуллин, Г.Ш.Гобәйдуллин, М.Ф.*Долгов*, Ф.Ф.*Фазылҗанов*, Ф.Г.*Надыйров*, И.К.*Хәйруллин*, Т.К.*Сәгыйтов*, Н.К.Хөснетдинов, И.Ю.*Әминов*, И.М.Мортазин, А.М.Сибагатуллин, 2011 дән Ф.С.Гыймалтдинов. Тапшыруларның баштагы күләме радиода тәүлегенә 4 *сәг.*, телевидениедә 3 *сәг.*, 1991 дә радиотапшыруларның вакыты 5 *сәг.*кә кадәр арттырыла, радиотапшырулар УКВ-ЧМда стереовариантта — 3 *сәг.*, телетапшырулар тәүлегенә 5 *сәг.*кә кадәр алып барыла башлый. 1996 да телетапшырулар 6 *сәг.*кә кадәр җиткерелә. 1997 нең августыннан радиотапшырулар 21, 31 һәм 49 *м* лы кыска дулкыннарда бара. 2002 нең 1 гыйнварына радиотапшырулар күләме: төп тапшырулар — 7 *сәг.*, УКВ-2 (стереофоник) — 3 *сәг.*, КВ тапшыру — 3 *сәг.*, «Азатлык» спутник аша тапшырулар программасы — 1 *сәг.*

*Әд.:* Тыңлагыз, Казан сөйли! — Слушайте, говорит Казань! К., 1998.

**ТАТАРСТА́Н ИКЪТИСА́Д ФӘННИ́-ТИКШЕРЕНҮ́ ИНСТИТУТЫ́**. ТАССР ХКС карары нигезендә 1930 елның мартында оештырыла. Максаты — фән казанышларын соц. төзелештә макс. файдалану, беренче бишьеллык план контекстында ТАССРның табигатен, табигый байлыкларын, икътисадын, мәдәниятен һәм көнкүрешен диалектик-материалистик күзлектән мөстәкыйль рәвештә өйрәнү; ТАССР терр-ясендәге дәүләт органнары, төрле фәнни һәм иҗтимагый оешмалар, ш.у. аерым фәнни хезмәткәрләрнең фәнни-тикшеренү эшчәнлеген координацияләү; хуҗалык һәм мәдәни төзелеш өлкәсендәге гамәли хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү, фәнни кадрлар әзерләү; фәнни белемнәрне популярлаштыру. Ин-т 3 бүлекне — сәнәгать-икътисад, а.х., мәдәният һәм көнкүреш бүлекләрен, 17 кабинетны берләштерә. Эшли башлаган елында ин-т аспирантурасына 17 кеше кабул ителә. Эшчәнлеге 3 юнәлештә алып барыла: тармакларга (кабинетларга) бүленеп эшләү шартларында тәҗрибәләр уздыру, материаллар һәм документлар туплау; ТАССР районнарын экспедицияләр оештырып өйрәнү; эшкә фәнни-тикшеренү, совет һәм җәмәгать оешмаларын җәлеп итү. Казанышларыннан берсен Татарстандагы гипс ятмалары турында мәгълүматлар алу һәм респ-када гипс эшләнмәләр җитештерүнең рентабельлелеген нигезләү тәшкил итә. Җир асты байлыклары һәм җир асты сулары кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәсендә ТАССРның файдалы казылмалары һәм геол. карталары төзелә. 1930 ел ахырына туфрак белеме кабинеты респ-ка туфракларының 10 чакрымлы җыелма картасын төзи. Тарих кабинеты хезмәткәрләре 16–17 йөзләрдә Идел-Кама төбәген колонияләштерү; Урал буе татарлары, типтәрләре һәм мишәрләре; татарлар тарихында төркичелек; Идел-Кама төбәгендә ислам, секталар һәм мәҗүсилек һ.б. темалар буенча эшлиләр. Ин-тта Ф.К.Сәйфи-Казанлының «Татарлар Февраль революциясенә кадәр» («Татары до Февральской революции», 1930), М.С.Сәгыйдуллинның «Вәисиләр хәрәкәте тарихына карата» («К истории ваисовского движения», 1930), С.Лившицның «Казан беренче революция елларында» («Казань в годы первой революции», 1930), П.М.Дульскийның «Революция чорында татар китабының бизәлеше» («Оформление татарской книги за революционный период», 1930), П.Красновның «Татарстанда 10 еллык (1920–1930 еллар) фәнни-тикшеренү эшчәнлеге» («Научно-исследовательская работа в Татарстане за 10 лет (1920–1930 гг.)», 1931) хезмәтләре әзерләнә. ТАССР ХКС Президиумының 1931 ел 27 май карары б-н ин-тның эшчәнлеге туктатыла. Аның нигезендә Татарстан сәнәгый-икътисади тикшеренүләр фәнни-тикшеренү ин-ты һәм Татарстан а.х. икътисады фәнни-тикшеренү ин-ты оештырыла. Ин-т директорлары — И.Р.Бурнаш, аның урынбасары — М.К.Корбут.

*Әд.:* Г а р и п о в а З. Татарский научно-исследовательский экономический институт // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2003. № 1/2; Х а й р у т д и н о в Р. Татарский научно-исследовательский институт культурного строительства им. М.Горького // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2009. № 2.

*В.А.Шагалов.*

**ТАТАРСТА́Н ИНТЕЛЛЕКТУА́ЛЬ МИЛЕ́К АГЕНТЛЫГЫ́**, коммерцияле булмаган иҗтимагый оешма. 1993 елда РФ Граждданнар кодексы нигезендә авторлык һәм аңа бәйле хокукларны саклау өлкәсендә тәкъдимнәр эшләү һәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, ш.у. авторлык һәм аңа бәйле хокукларга караган законнарның ТР терр-ясендә үтәлү-үтәлмәвен күзәтү максаты б-н ТР МК каршында оештырыла. Хөкүмәт карары б-н 2002 нең 1 гыйнварыннан ябыла. Аның урынына 2002 нең гыйнварында шул исемдә һәм шул ук максатларда эшли торган иҗтимагый оешма барлыкка килә. Индивидуаль рәвештә авторлар һәм башкаручылар хокукларын тәэмин итү мөмкин булмаган очракта, агентлык бу эшне үз өстенә ала (мәс., халык алдында муз. әсәр башкарганда, сәнгать әсәрләренең репродукцияләрен ясаганда, авторларга акчалата түләү). Ирекле әгъзалык һәм демократик үзидарә принциплары нигезендә яшәп килә. 2014 нең 1 гыйнварына оешмада якынча 1200 кеше санала.

**ТАТАРСТА́Н КӘСЕПЧЕЛЕ́К КООПЕРАТИВЛАРЫ́ СОВЕТЫ́** (Татпромсовет). 1932 елның сентябрендә Казанда Кәсепчелек кооперативлары берлеге җирлегендә барлыкка килә. 1946–50 елларда ТАССР МС каршындагы кәсепчелек кооперацияләре идарәсе. Төп максаты — ТАССРдагы кәсепчелек кооперацияләре оешмаларын берләштерү һәм алар эшчәнлегенә җитәкчелек итү (эшләрен планлаштыру, исәп-хисап алып бару һ.б.). Таткожвалпромсоюз (1932–56), Татремонтпромсоюз (1953 кә кадәр), Татшвейтекстильпромсоюз (1953 тән), Татпищепромсоюз (1947 дән), Татлеспромсоюз (1953–55), Татмебельпромсоюз (1953–55), Татстройметаллпромсоюз (1954 тән), Татстройпромсоюз (1932–54), Татметаллпромсоюз (1942–54), Татразнопромсоюз (1932–52), Таттранспромсоюз (1953 кә кадәр), Татбытпромсоюз (1953 тән), Татпромснабсбыт (1940–53), Казгорбытпромсоюз (1944–54 тә Казгоррембытсоюз), Татмногопромсоюз (1952 нең августына кадәр Казгормногопромсоюз), Казгоршвеймехпромсоюз (1945–53), Таткоопинсоюз (1953 кә кадәр) һ.б.ны берләштерә. 300 дән артык артель керә (1953). 1956 ның апрелендә эшчәнлеге туктатыла.

**ТАТАРСТА́Н КИТА́П НӘШРИЯТЫ́**. 1919 елның 22 июлендә РКП(б)ның Казан губерна ком-ты карары нигезендә Дәүләт нәшриятының Казан бүлеге оеша, 1920 нең 3 ноябрендә РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты карары б-н Татарстан дәүләт нәшрияты (Татгосиздат) итеп үзгәртелә. ВКП(б) өлкә ком-тының 1922 ел 30 ноябрь карары нигезендә нәшрият «*Татпечать*» тресты б-н берләштерелә, һәм шулар нигезендә Татарстан нәшрият һәм матбугат комб-ты оеша. 1926 да ул Татарстан дәүләт нәшрияты (Татгиз) итеп үзгәртелә. 1927 дән, аның составыннан К.Якупов исем. полиграфия комб-ты чыгарылып, «Гажур» газета-журналлар берләшмәсе кушылгач, Татарстан нәшрияты (Татиздат) исемен ала; 1933 тән, полиграфия комб-ты б-н кабат берләштерелүдән соң, — Татарстан дәүләт нәшрияты (Татиздат), 1954 тән — Татарстан китап нәшрияты (Таткнигоиздат). 1958 дә Татарстан полиграфия пр-тиесе (Татполиграф) һәм Татарстан китап сәүдәсе (Таткниготорг) аерылып чыкканнан бирле хәзерге исемдә. Оешкан вакыттан ук татар телендә фәнни-популяр иҗтимагый-сәяси һәм матур әдәбият нәшер итүче иң зур оешма була. 1931 гә, барлык шәхси һәм кооператив нәшрият, басмаханәләр (фәнни әдәбият нәшер итүче югары уку йортларыннан кала) ябылганнан соң, — ТАССРдагы бердәнбер нәшрият, 1932 дән (Үзәк нәшриятның Татарстан бүлеге бетерелгәннән соң) 1991 гә кадәр СССРдагы татар телендә әдәби басмалар бастыручы бердәнбер үзәк була. 1924 тә — 69, 1926 да — 223, 1933 тә — 913, 1963 тә — 1006 (ш.и. 593 е — татар телендә) исемдәге китап басыла. 1970–80 еллар башында татар телендәге басмалар саны кими (1970–80 дә 300 гә якын китап чыга). 1991 дә Т.к.н.нан «*Мәгариф*» нәшрияты бүленеп чыга. Нәшрият китапларның яртыдан артыгын — татар, якынча өчтән бер өлешен рус телендә чыгара. 2015 тә 265 исемдәге китап басыла, ш.и. 210 сы — татар, 55 е — рус телендә, тиражы — 601,66 мең данә. Т.к.н.нда күп кенә күренекле язучылар, журналистлар, галимнәр, рәссамнар хезмәт куя: С.С.*Атнагулов*, Ф.*Сәйфи-Казанлы*, Б.М.*Әлминов*, И.Г.*Ахунҗанов*, Г.А.*Ахунов*, Ф.*Бурнаш*, Р.Н.*Даутов*, Т.К.*Журавлёв*, Э.Я.*Зарипов*, Г.*Кашшаф*, Г.М.*Минский*, Г.*Нигъмәти*, З.*Нури*, К.*Нәҗми*, Г.*Толымбай*, Н.*Фәттах*, М.*Хөсәен* һ.б. 2010 нан «Мәгариф» нәшрияты б-н берләш-

тереләә. Нәшрият җитәкчеләре: Н.Г.Мохтаров (1925–27), С.З.Шәрәфетдинов (1927–33), В.С.*Шәфигуллин* (1934–39), М.Х.*Гайнуллин* (1942–44), С.Б.Вәлиди (1957–63), Г.Г.Камалиев (1963–73), Г.Н.*Шәрәфетдинов* (1973–87), Р.С.*Мөхәммәдиев* (1987–89), Х.Ә.*Әшрәфҗанов* (1989–98), Д.С.Шакиров (1998–2015), И.К.Сәгъдәтшин (2015 тән).

*Әд.:* Каталог книг, выпущенных Татарским государственным издательством «Таттосиздат» при Совнаркоме ТАССР. К., 1936; Книги Татарского книжного издательства за 9–10 пятилетки. К., 1982; Книги Татарского книжного издательства за 11-ю пятилетку. К., 1987; Здравствуй, Книга! К., 1989; Каримуллин А.Г. Татарское государственное издательство и татарская книга России (1917–1932). К., 1999.

**«ТАТАРСТА́Н КОЛХОЗЧЫСЫ́»** («Колхозник Татарии»), танк колоннасы. 1943 елда Татарстан халкыннан җыелган акча исәбенә төзелә. 1942 нең көзендә Саба р-ны яшьләре танк колоннасы төзү өчен акча җыю тәкъдиме б-н чыга: «... һәр район җыелган акчага берәр танк төзесен». 1943 ел башына 100 млн. сум җыела (45 млн. сумны яшьләр, ш.и. комсомоллар җыя). 1943 нең маенда ТАССР делегациясе Иске Оскол шәһәре янында «Т.к.» сүзләре язылган 200 танкны генерал-лейтенант В.Г.Бурков җитәкчелегендәге 10 нчы танк корпусы сугышчыларына тапшыра.

*Әд.:* Гильманов З.И. Татарская АССР в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг. К., 1977.

*В.Ф.Телишев.*

**«ТАТАРСТА́Н КОММУНИСТЫ́»**, к. *«Коммунист Татарии»*.

**«ТАТАРСТА́Н КОМСОМОЛЫ́»** («Комсомолец Татарии»), танк колоннасы, 1942 елда Татарстан халкыннан җыелган акчага төзелә. 1941 нең ноябрендә яшьләр, ш.и. Яшел Үзән шәһәре, Казан шәһәренең Совет р-ны һәм Чистай р-ны комсомоллары танк һ.б. хәрби техника төзү өчен акча җыю тәкъдиме б-н чыга. 1941 нең 23 ноябрендә респ-када 275 мең кеше катнашында комсомол яшьләрнең якшәмбе өмәләре уза. Танк колоннасы төзү фондына 1 млн. 340 мең сум акча, 103 мең чамасы хезмәт көне күчерелә; 1942 нең февраленә «Т.к.»н төзүгә 2270 мең сум акча, самолётлар төзүгә 9 млн. сум акча җыела.

*Әд.:* Гильманов З.И. Татарская АССР в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг. К., 1977.

*В.Ф.Телишев.*

**ТАТАРСТА́Н КО́НКУРЕШ КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́ БЕРЛЕГЕ́** (Татбытпромсоюз), 1937 елның апрелендә Казанда Татарстан һөнәрчелек-кәсепчелек берлеге буларак оештырыла, 1953 нең сентябреннән шушы исемдә. Максаты — өс һәм аяк киемнәрен төзекләндерү һәм тегү артельләренең хуҗалык һәм финанс эшчәнлегенә җитәкчелек итү. 32 артельне берләштерә. *Татарстан кәсепчелек кооперативлары советына* буйсына. 1957 нең июнендә эшчәнлеге туктатыла.

**ТАТАРСТА́Н КҮ́ПТӨРЛЕ КӘСЕПЧЕЛЕКЛӘ́Р БЕРЛЕГЕ́** (Татразнопромсоюз), 1932 елның маенда Казанда оештырыла. 30 артельне берләштерә. Максаты — артельләрнең хуҗалык һәм финанс эшчәнлегенә җитәкчелек итү. *Татарстан кәсепчелек кооперативлары советына* буйсына. 1952 нең августында атамасы Казан өлкәсе кәсепчелекләре берлеге (Казоблмногопромсоюз) дип, 1953 нең апрелендә ТАССРның күпләгән кәсепчелекләр берлеге (Татмногопромсоюз) дип үзгәртелә. 1957 дә эшчәнлеге туктатыла.

**«ТАТАРСТА́Н КЫРЫ́»**, к. *Татарстан авыл хуҗалыгы институты*.

**ТАТАРСТА́Н МЕТА́ЛЛ ЭШКӘРТҮ́ КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́ КООПЕРАТИВЛАРЫ́ БЕРЛЕГЕ́** (Татметаллпромсоюз), 1935 елның мартында Казанда оештырыла. Максаты — ТАССРдагы металл эшкәртү, металл эшләнмәләр җитештерү кооперативларының (артельләрнең) эшчәнлегенә җитәкчелек итү. 19 артельне берләштерә. Бөтенроссия металл эшкәртү кооперативлары берлегенә һәм *Татарстан кәсепчелек кооперативлары советына* буйсына. 1954 нең декабрендә эшчәнлеге туктатыла.

**ТАТАРСТА́Н МЕХ ҖИТЕШТЕРҮ́ БЕРЛӘШМӘСЕ́**, к. *«Мелита»*.

**ТАТАРСТА́Н НЕФТЬ МАШИНАЛАРЫ́ ТӨЗҮ́ ИНСТИТУТЫ́**, фәнни-тикшеренү һәм проект-конструкторлык ин-ты (ТатНИИнефтемаш), 1963 елда Әзәрбайҗан нефть машиналары төзү фәнни-тикшеренү һәм проект-конструкторлык ин-тының (ӘзНИИмаш) Казан ф-лы буларак оештырыла. 1971 дә ТатНИИнефтемашка үзгәртелә, 1996 дан — АҖ. Нефть, газ һәм су чыгару, туплау, әзерләү, саклау һәм ташу; катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру, углеводородлар чыгарганда һәм ташыганда әйләнә-тирә мохитне саклау; скважиналарга капиталь һәм җир асты ремонты, нефть чыгаруда авыр процессларны механикалаштыру җайланмаларын һәм күчмә нефть промыселы агрегатларын, җиһазларның төзеклеген тикшерү һәм төзәтү җиһазларын проектлау буенча тикшеренүләр үткәрә. ТР һәм РФ заводларында серияле җитештерү оештырыла: җиһазларның 500 дән артык төре җитештерелә (кайберләре чит илгә чыгарыла). РФдә беренче тапкыр диңгез скважиналарын үзләштерү җиһазлары комплексы эшләнә (Таз култыгы акваториясендә гамәлгә кертелә). Уйлап табуга һәм файдалы үрнәкләргә 600 гә якын авторлык таныклыгы һәм патенты алынган. «Татнефть» АҖдә гамәлгә кертелгән искергән шиннарны һәм резина калдыкларын утильләштерү комплексы эшләгән өчен, ин-т хезмәткәрләренә ТР Дәүләт бүләге бирелә (2002). Ин-тның эшләре ТР Хөкүмәте бүләге (2004), РФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге (2008), «Архимед-2006», Халыкара «Архимед» салонының 4 алтын һәм 4 көмеш медальләре б-н билгеләнә.

Ин-т җитәкчеләре: И.А.Бувайло (1963–82), У.К.Мөхәммәтҗанов (1982–87), И.Г.Хисамиев (1987–89), А.Ф.*Садыйков* (1989 дан).

**ТАТАРСТА́Н НЕФТЬ ФӘННИ́-ТИКШЕРЕНҮ́ ҺӘМ ПРОЕ́КТ ИНСТИТУТЫ́**, В.Д.Шашин исем. «Татнефть» АҖ карамагында (ТатНИПИнефть). 1956 елда Татарстан нефть фәнни-тикшеренү ин-ты («ТатНИИ») буларак Бөгелмә шәһәрендә нигезләнә. 1970 тә «ТатНИИ» һәм «Татнефтепроект» ин-тлары җирлегендә ТатНИПИнефть оештырыла. 1978–93 тә Казанда әлеге ин-тның Казан комплекслы фәнни-тикшеренү бүлеге эшли. Ин-т нефть чыганаклары геологиясе һәм эшкәртү, скважиналар төзү, аларны эшләтү һәм төзекләндерү, катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру, нефть, газ һәм суны чыгаруга әзерләү, нефть чыгару җиһазларын тутыгудан саклау, әйләнә-тирә мохитне саклау, мәгълүмати технологияләр, икътисад, нефть чыганакларын урнаштыруны проектлау, сәнәгый һәм гражданлык төзелеше буенча киң комплекслы фәнни-тикшеренү һәм проект эшләре алып бара.

Ин-т хезмәткәрләренең саны — якынча 1000 кеше, ш.и. 13 фән. д-ры һәм 63 фән. канд. (2016). Уйлап табуга 2500 дән артык авторлык таныклыгы һәм патенты, шуларның 15 енә 73 чит ил дәүләтләре патенты алына, 83 фәнни хезмәтләр җыелмасы һәм 228 монография, 8800 фәнни мәкалә басыла (2016).



ТатНИПИнефть.

Фәнни хезмәтләр Ленин бүләгенә, СССРның фән һәм техника өлкәсендә 3 Дәүләт бүләгенә, РФ Хөкүмәте бүләгенә, ТРның фән һәм техника һ.б. өлкәсендә 17 Дәүләт бүләгенә лаек була.

Ин-тта эшләнгән технологияләр һәм җиһазлар Россиядәге нефть чыгаручы компанияләрдә генә түгел, ә күп кенә якын һәм ерак чит илләрдә дә киң кулланылыш таба.

2000 нән ТатНИПИнефть каршында скважиналарны бораулау һәм үзләштерү, нефть һәм газ чыганакларын эшкәртү һәм үзләштерү белгечлеге буенча кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклау буенча диссертация советы эшли.

Ин-т җитәкчеләре: В.А.Еронин (1956–64), Г.Г.*Вахитов* (1964–71), Р.Т.*Булгаков* (1972), Ф.М.Хәмәдиев (1972–78), Р.Х.*Ибәтуллин* (1978–97), И.Г.*Йосыпов* (1997–2000), Р.Р.*Ибәтуллин* (2000–14), Р.З.Сәхәбетдинов (2014 тән).

**«ТАТАРСТА́Н ПА́РТИЯ ОЕШМАСЫНДА́ МА́ССА-ПОЛИ́ТИК ҺӘМ ИДЕОЛО́ГИЯ ЭШЕНЕ́Ң ТОРЫШЫ́ ҺӘМ АНЫ́ ЯХШЫРТУ́ ЧАРАЛАРЫ́ ТУРЫНДА́»**, ВКП(б) ҮКның 1944 ел 9 август карары. ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты секретаре В.Д.Никитин һәм ВКП(б) ҮКның Пропаганда һәм агитация идарәсе башлыгы урынбасары М.Т.Иовчук докладлары буенча кабул ителә. Карарда түбәндәгеләр билгеләнә: респ-када масса-политик һәм идеология эшенең таркалган булуы, ВКП(б) Татарстан өл-

кә ком-ты тарафыннан респ-ка һәм район газеталары редакцияләре эше, ш.у. мәдәни-агарту учреждениеләренең эше б-н канәгатьләнерлек дәрәҗәдә җитәкчелек итмәү; Татарстан шәһәрләрендә һәм авылларында яшәүче халыкны сәяси мәгълүмат б-н җитәрлек дәрәҗәдә таныштырмау; ВКП(б) ҮКның җирле радиотапшырулар оештыру турындагы карары булса да, 29 районда радиотапшырулар булмау. Карарда күрсәтелгәнчә, «Татарстан өлкә ком-ты партия тарихы өлкәсендәге идеология эшен Татарстан тел, әдәбият һәм тарих ин-тына ышанып тапшыра, язучылар һәм сәнгать эшлеклеләре иҗаты б-н канәгатьләнерлек дәрәҗәдә җитәкчелек итми, интеллигенция арасында идея-сәяси тәрбия эшен оештырмый, нәтиҗәдә, респ-када татар халкы тарихын яктыртуда, ш.и. татар әдәбиятында һәм сәнгатендә идеологик характердагы җитди хаталар урын алып тора». ВКП(б) ҮК массакүләм сәяси һәм идеология эшенең җитешсезлеген бетерү өчен, ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тына җитәкче сәяси органнарның көчләрен туплауны йөкләгән карар чыгара. Моның өчен авыл һәм шәһәр интеллигенциясенең, партия һәм комсомол хезмәткәрләренең, авыл коммунистларының һәм комсомолларының һ.б.ның гомуми идеологик аң дәрәҗәсен үстерү максатыннан төрле сәяси курслар, ш.и. сәяси-агарту өлкәсендәге хезмәткәрләр өчен 6 айлык курслар оештыру; уку залларын, мәдәният йортларын, район китапханәләрен, Алабуга шәһәренең китапханә техникумы эшен торгызу буенча чаралар күрү; барлык эшләмәүче кино аппаратураларын ремонтлау һәм һәрбер авыл советында ким дигәндә айга 1 тапкыр кинофильмнар күрсәтүне тәэмин итү; барлык районнарда да җирле радиотапшырулар оештыру көздә тотыла. Татарстан өлкә ком-тына Татарстан тарихын фәнни өйрәнүне оештырырга, аны яктыртканда милләтчелек рухындагы җитди ялгышлар һәм җитешсезлекләрне бетерергә тәкъдим ителә. ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тына Татарстан тел, әдәбият һәм тарих ин-тының эшен җентекләп тикшерү йөкләнә.

1945 нең 24–27 февралендә өлкә ком-ты пленумы була, анда ҮК карарларының тормышка ашырылу мәсьәләсе карала. Өлкә ком-ты секретаре С.И.Маловның идеология мәсьәләсенә багышланган докладында җибәрелгән «хаталар»га һәм «ялгышлар»га, бигрәк тә Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты хезмәткәрләренең эшендәге кимчелекләргә игътибар ителә. Галимнәрне рус һәм татар халкының чит ил илбасарларына каршы бердәм көрәшен өйрәнәсе урында 12–16 йөзләр әдәбиятына караган чыганакларны тикшерүдә гаепплиләр. Докладта галимнәрнең Алтын Урданы мәдәни һәм икътисади яктан бик нык алга киткән прогрессив дәүләт буларак танулары ялгышлык дип күрсәтелә, Алтын Урданың агрессивлыгы, рус җирләренә юлбасарларча һөҗүм итүләре, шул дәүләттә яшәгән халыкларның рәхимсез изелүе фаш ителә. «Идегәй» дастаны турында: «Берничә ел дәвамында... бу эпос татар халкының героик эпосы буларак бөтенләй хаксыз рәвештә популярлаштырылды. Шул ук вакытта «Идегәй» дастанының милләтчелек идеяләре чагылышы булуы турында бер сүз дә әйтелмәде», — диелә. Татарстан өлкә ком-тының 1 нче секретаре З.И.Моратов иң элек тарихчы Хәйри *Гыйммадины* һәм язучы Нәкый *Исәнбәтне* гаепли. Галимнәрнең тикшеренүләрендә һәм язучыларның иҗатында халыкларның интернациональ дуслыгы, татарларның революцион хәрәкәткә керткән өлеше темалары яктыртылырга тиешлеге күрсәтелә. Бу карар татар халкының тарихын тирәнтен тикшерүдә, мәдәниятен үстерүдә зур кыенлыклар һәм тоткарлык тудыра, язучылар, композиторлар һәм сәнгать осталары иҗатына тискәре йогынты ясый.

*Әд.:* Т а г и р о в И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999.

*Б.Ф.Солтанбәков.*

**«ТАТАРСТА́Н ПЕДАГО́ГИЯ ҖӘМГЫЯТЕ́ ХӘБӘРЛӘРЕ́»**, айлык журнал. ТАССР Мәгариф халык комис-ты каршында эшләп килгән Пед. җәмгыяте органы. 1928–30 елларда татар телендә — гарәп графикасында, 1930 да латин графикасында нәшер ителә. 1930 ның 5–6 нчы саннарында материаллар татар һәм рус телләрендә басыла. Татарстан Пед. җәмгыятенең эшчәнлеге яктыртыла, мәгариф өлкәсендәге алдынгы тәҗрибә пропагандалана. Күп кенә язмаларның авторлары оешма җитәкчеләре Х.Абдуллин, Г.Бакиров, М.Корбангалиев, И.Рәхмәтуллин, М.Сафин, И.Меденцев була. Оешма эшчәнлегенең оештыру якларын яктыртуга күп урын бирелә: эш планнары, аларның үтәлеше турында хисап, оешма советы, президиумы һәм секретариаты тарафыннан тикшерелә торган мәсьәләләр, ул мәсьәләләр буенча кабул ителгән карарлар турында мәгълүмат басыла, җәмгыятьнең кадрлар составы турында белешмәләр бирелә. «Башка фәнни җәмгыятьләр тормышы турында мәгълүматлар» бүлегендә Мәскәү, Түбән Новгородның фәнни оешмалары турында хәбәр ителә. «Фәнни докладлар тезислары», «Мәгариф дөньясында», «Сорауларга җаваплар» рубрикалары була. Журналның соңгы санының күпчелек өлеше Пед. җәмгыятенең яңа структурасын сурәтләүгә багышлана.

*З.З.Гыйләҗев.*

**ТАТАРСТА́Н РӘССАМНАРЫ́ ТӘШКИЛӘТЕ́**, ТР рәссамнары һәм сәнгать белгечләренең иҗат берләшмәсе. 1991 елда элекке ТССР Рәссамнар берлеге әгъзалары катнашында узган оештыру съездында рәсмиләшә. Чаллы шәһәрендә ф-лы ачыла. 1995 тә берләшмәгә яшь рәссамнарның «Дастан» иҗат коллективы кушыла. 1999 да берләшмә яшәүдән туктый.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКА АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ ТӘҖРИБӘ́ СТА́НЦИЯСЕ**, 1957 елда *Казан селекция станциясен*, бәрәңге-яшелчә, бакчачылык, терлекчелек, умартачылык махсуслаштырылган тәҗрибә станцияләрен берләштерү юлы б-н оештырыла. 1964 тә станциянең игенчелек бүлеге эше өчен терәк пунктлар сыйфатында 5 тәҗрибә кыры булдырыла: Бөгелмә, Чистай, Буа, Арча, Столбищеда; элита орлыклар җитештерү өчен 1960 та аның карамагына «*Столбище*», «Красный Октябрь», «*Орлыкчылык*» с-злары, 1967 дә Ленин исем., «Ямашев», «Кыят» с-злары бирелә. 1969 ның ахырында станция җирлегендә *Татарстан авыл хуҗалыгы институты* булдырыла. 1969 га а.х. файдалану җирләренең гомуми мәйданы 95 мең *га* га җитә (ш.и. сөрү җирләре 68 мең *га* дан күбрәк), терлекләр саны — 17 мең баштан артык. Эшчеләр, хезмәткәрләр, белгечләр һәм фәнни хезмәткәрләр — якынча 6 мең кеше. Станциядә 10 фәнни бүлек һәм 2 лаб. бар, аларда 20 дән артык фән д-ры һәм фән канд-тлары эшли. Т.р.а.х.т.с.ндә чыгарылган сортлар: көзге арыш — «*Татарская 1*», көзге бодай — «Стрела», язгы бодай — «Лютесценс 20/101», «Альбидум 7», карабодай — «*Майская*». «*Краснострелецкая*», тары — «Казан 2», «Казан 61», «Казан 207», борчак — «Казан 38», бәрәңге — «Питрәч», люцерна — «Казан 32», алмагач — «Татар ренеты», чия — «Ранняя сладкая», «Теньковская», кура җиләге — «Юбилейная», «Теньковская ранняя», каен җиләге — «Татарстан»; гибридлар: кукурузлар — «Татарский 6», «Коллективный 6 ТВ», «Коллективный 10 ТВ», томатлар — «Матросовский», «Докучаевский 4». Бөртекләр һәм бөртекле-кузаклы культуралар, шикәр чөгендере, бәрәңге һәм башка а.х. культураларын, бәрәңге орлыкчылыгын, бөртекле һәм терлек азыгы культураларын (ш.и. болын-көтүлек үләннәрен) үстерү, ашламалар куллану технологиясен камилләштерү буенча фәнни эшләр уздырыла. Сәнгать бакчалары оештыру буенча җиләк-җимеш хуҗалыкларында чаралар системасы эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Чәчү әйләнешен өйрәнү, тамыр үрентеле чүп үләннәре һәм кара солы б-н көрәш буенча, сугарулы игенчелек, туфракны эрозиядән саклау, хайван токымнарының продуктлылыгын яхшырту, холмогор токымлы терлекләрнең сөтлелеген һәм сөтнең майлылыгын арттыру, сәнәгатьтә дуңгызларны аталандыру, ит терлекчелегенә, сарык асрау һәм кошчылыкка, бестужев һәм швиц токымлы сыерларны абердин-ангус токымлы үгезләр б-н кушылдыру, прекос токымлы сарыклар б-н селекция-нәсел эше, ит тавыклары һәм бройлерлар үстерү өчен кроссларны өйрәнү, җирле бал кортларының продуктлылыгын яхшырту буенча эш тематикасы киңәйтелә. Тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгы станцияләре ел саен колхоз һәм совхозларга 20–30 мең *т* элита һәм югары продуктлы орлык җитештереп җибәрә. ТР а.х. тәҗрибә станциясенең а.х. фәне үсешенә иң зур өлеш керткән галимнәре: А.А.*Җиһаншин*, Х.Х.*Байчурова*, В.З.*Шәкуров*, Ш.В.*Вәлиев*, Г.И.*Розанова*, М.Н.*Шумкова*, Н.Н.*Петелина*, Х.Г.Бакжанов, Җ.Х.*Шәрәф*, А.С.Титова, А.М.Ростачков, Л.А.*Севастьянова*, Ф.М.*Киселёва*, Л.А.Киселёва, В.И.Логинов, Н.И.Вакуленко, А.А.*Надысева*, В.В.Алпатов.

Т.р.а.х.т.с. җитәкчеләре: Н.П.Матвеев (1957), Г.А.Рюмина (1960–61), Ю.Х.Миндубаев (1961–63), Ү.Г.*Биктимеров* (1963–69).

*Әд.:* Татарскому научно-исследовательскому институту сельского хозяйства — 50 лет. К., 1971.

*И.Н.Афанасьев.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ** (Татарстан, ТАССР, ТССР, ТР).


I. ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР ........ 559
Хокукый статус .................... 559
Административ-территориаль бүленеш .......................... 559
Халкы .......................... 560
Дин ............................ 560
II. ФИЗИК-ГЕОГРАФИК ОЧЕРК ...... 561
III. ТАРИХИ ОЧЕРК .................. 570
IV. СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДИ ҮСЕШ ... 577
Сәнәгать .......................... 578
Төзелеш .......................... 581
Транспорт ........................ 583
Элемтә ............................ 584
Агросәнәгать комплексы ............ 585
Торак-коммуналь хуҗалык ......... 587
Банк эше .......................... 588
Сәүдә һәм җәмәгать туклануы ....... 588
V. ТЫШКЫ ИКЪТИСАДИ ҺӘМ ТӨБӘКАРА ЭЛЕМТӘЛӘР ..... 589
VI. СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ............ 590
VII. МӘДӘНИЯТ ........................ 591
Халык мәгарифе .................... 591
Фән ................................ 592
Әдәбият ............................ 596
Музыкаль культура ................ 596
Театр сәнгате ...................... 598
Кино ............................... 600
Сынлы сәнгать һәм бизәлеш сәнгате . 600
Архитектура ....................... 603
Китап бастыру эше ................. 605
Китапханәләр ...................... 605
Музейлар .......................... 606
VIII. МАССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫ .......................... 607
IX. ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТ .. 609
X. ТР ДӘҮЛӘТ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ОЕШМАЛАРЫНДА ТАТАРЛАРНЫҢ РЕСПУБЛИКАДАН ЧИТТӘ ТУПЛАНЫП ЯШӘҮ УРЫННАРЫНДАГЫ МӘДӘНИ-АГАРТУ ЭШЕ ..... 611


## I. ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР

Татарстан Республикасы — *Россия Федерациясе* составындагы демократик, хокукый дәүләт. РСФСР БҮБК һәм ХКСның 1920 ел 27 май Декреты нигезендә төзелә. Мәйданы — 67,8 мең *км*². Көнбатышта — Чуаш Респ-касы, төньяк-көнбатышта — Мари Респ-касы, төньякта — Киров өлкәсе, төньяк-көнчыгышта — Удмурт Респ-касы, көнчыгышта — Башкортстан Респ-касы, көньяк-көнчыгышта — Оренбург өлкәсе, көньякта — Самара һәм Ульянов өлкәләре б-н чиктәш.

Респ-када 43 район, 22 шәһәр (14 — респ-ка һәм 8 — район карамагындагы), 18 шәһәр тибындагы посёлок, 3082 авыл торак пункты исәпләнә. Иң зур шәһәрләр — Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Яшел Үзән, Бөгелмә, Алабуга. Башкаласы — *Казан*.

**Хокукый статус**. Респ-каның статусы РФ Конституциясе, *Татарстан Республикасы Конституциясе*, РФ һәм ТР арасындагы *«Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында»* шартнамә (2007 нең 26 июнендә РФ Президенты В.В.Путин, ТР Президенты М.Ш.Шәймиев кул куя; 2007 нең 24 июлендә Федераль закон буларак раслана) нигезендә билгеләнә. Респ-када дәүләт башлыгы — *Татарстан Республикасы Президенты*, ул ТРның югары башкарма һәм дәүләт идарә органнары системасы б-н җитәкчелек итә (беренче Президент — М.Ш.*Шәймиев*, 1991 нең июне — 2010 ның марты; 2010 ның мартыннан — Р.Н.*Миңнеханов*). Иң югары законнар чыгару органы — *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы*. Башкарма идарәне респ-ка хөкүмәте — *Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты* җитәкли. Мәхкәмә системасы *Татарстан Республикасы Конституция мәхкәмәсеннән, Татарстан Республикасы Югары мәхкәмәсеннән, Татарстан Республикасы Арбитраж мәхкәмәсеннән,* район мәхкәмәләреннән һәм җәмәгать мәхкәмәләреннән гыйбарәт. Дәүләт хакимияте органнары ТР Конституциясе, РФ һәм ТР законнары нигезендә оештырыла. Татарстан Республикасы Прокуратурасы РФ һәм ТР Конституцияләренең һәм законнарының үтәлешенә күзәтчелек итә. Рәсми символлар — *Татарстан Республикасы Дәүләт гербы, Татарстан Республикасы Дәүләт гимны, Татарстан Республикасы Дәүләт флагы.* Респ-каның рәсми исеме берничә тапкыр үзгәрә: 1920 нең 27 маеннан — Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы (ТАССР), 1990 ның 30 августыннан — Татарстан Совет Социалистик Республикасы (ТССР); 1992 нең 7 февраленнән — Татарстан Республикасы. Дәүләт телләре — татар һәм рус телләре.




Татарстан Республикасы Дәүләт гербы.



Татарстан Республикасы Дәүләт флагы.

**Административ-территориаль бүленеш**. Респ-ка төзелгәндә аның составына Казан, Вятка, Самара, Сембер, Уфа губерналарының өяз һәм волостьлары кертелә. 1920 еллар ахырында ТАССР 10 кантонга — Арча, Бөгелмә, Буа, Зөя, Лаеш, Мамадыш, Минзәлә, Спас, Тәтеш, Чистай кантоннарына бүленә; респ-када 11 шәһәр була: Казан, Арча, Бөгелмә, Буа, Зөя, Лаеш, Мамадыш, Минзәлә, Спас, Тәтеш, Чистай. 1921 дә ТАССР составына Вятка губернасының берничә волосте һәм Алабуга шәһәре кертелә. Шул ук елда тагын 3 яңа кантон — Алабуга, Чаллы һәм Әгерҗе (1924 тә бетерелә) кантоннары оештырыла. 1920–21 дә респ-ка чикләрен тәгаенләү эше активлаша, 1921 дә ТАССР б-н Самара, Сембер, Вятка губерналары, ш.у. Мари, Чуаш, Вотяк автономияле өлкәләре арасындагы кайбер торак пунктлар һәм волостьлар бер-берсенә тапшырыла. 1924 тә респ-када волостьлар саны 223 тән 125 кә кадәр кими. Үзгәрешләр ш.у. шәһәрләргә дә кагыла: 1921 дә Әгерҗе һәм Чаллы кантоннары төзелү сәбәпле, аларның үзәкләре Әгерҗе һәм Чаллы шәһәре дип үзгәртелә; 1926 да әлеге шәһәрләр һәм Арча, Лаеш яңадан авыл дип санала башлый. 1926 ның ахырында ТАССРда 10 шәһәр исәпләнә: Казан, Бөгелмә, Буа, Алабуга, Мамадыш, Минзәлә, Зөя, Спас, Тәтеш, Чистай.

1927 дә ТАССРны районлаштыру эше башлана, беренче районнар төзелә башлый (1930 га кадәр адм.-терр. бүленешнең катнаш кантон-район системасы гамәлдә була), Лаеш, Зөя, Тәтеш, 1928 дә Алабуга кантоннары бетерелә. 1930 да катнаш бүленеш районнарга бүленеш б-н тулысынча алмашына; 106 волостьтан торган 8 кантон урынына 38 яңа район (8 район инде моңарчы була) оештырыла. Районнарның саны 46* га җитә.

1930 елларда Чаллы (1930), Зеленодольск (Яшел Үзән) (1932), Әгерҗе (1938) шәһәр статусы ала. 1932 дә Зөя шәһәре авыл итеп үзгәртелә. 1930 еллар ахырында респ-када 12 шәһәр була: Казан, Әгерҗе, Бөгелмә, Буа, Алабуга, Зеленодольск, Куйбышев, Мамадыш, Минзәлә, Чаллы, Тәтеш, Чистай. 1930–40 елларда ТАССРның адм.-терр. бүленешенә яңа үзгәрешләр кертелә: 29 район төзелә (1931 дә — 1, 1935 тә — 17, 1938 дә — 4, 1944 тә — 7 район), 5 район* бетерелә (1931 дә — 3, 1932 дә — 1, 1938 дә — 1 район). 1935, 1938 һәм 1944 елларда яңа районнар оешу кайберләренең кечерәк районнарга бүленүе б-н бәйле. 1944 тә районнар саны 70 кә җитә.

1952 дә респ-ка 2 өлкәгә — Казан (37 район керә) һәм Чистай (33 район) өлкәләренә бүленә; 1953 нең февралендә 3 нче — Бөгелмә өлкәсе (18 район) оештырыла; шул ук елның апрелендә (Н.С.Хрущёв КПСС ҮКының 1 нче секретаре булып сайлангач) бу өлкәләр таркатыла.

1950 еллар уртасыннан илдә адм. берәмлекләр саны кыскара башлый. 1954–60 та ТАССРда 24 район бетерелә (1954 тә — 3, 1956 да — 4, 1958 дә — 5, 1959 да — 10, 1960 та — 2). 1963 тә партия-дәүләт органнарын җитештерү принцибы буенча үзгәртү кампаниясе уза: районнар авыл һәм сәнәгать р-ннарына бүленә. 1963 тә 29 район бетерелә, яңа чикләрдәге 1 сәнәгать һәм 17 үзәкләштерелгән авыл районы* оештырыла. Ләкин тиздән мондый бүленешнең бик үк уңышлы булмавы ачыклана. 1964 тә 3 яңа авыл районы,

1965 тә тагын 15 район* оештырыла; авыл районнары районнар итеп үзгәртелә, сәнәгать районы бетерелә.

1960 елларның 2 нче яртысыннан 1990 елларның башына кадәр ТАССРда күп кенә яңа районнар оештырыла: 1966 да — Чүпрәле, 1972 дә — Зәй, 1983 тә — Яңа Чишмә, 1985 тә — Менделеев, 1990 да — Әтнә, 1991 дә Ютазы, Кайбыч, Теләче р-ннары. 1950 еллардан Әлмәт (1953), Лениногорск (1955), Түбән Кама (1966), Менделеев (1967), Зәй (1978), Азнакай (1987), Баулы (1997), Нурлат (1997) шәһәр статусы ала, 2004 тә — Лаешка, 2008 дә Арчага шәһәр статусы кайтарыла. 2010 ел башына респ-када 43 район* исәпләнә.

Хәзер Татарстанда 22 шәһәр: 14 респ-ка карамагындагы (Казан, Азнакай, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Буа, Алабуга, Зәй, Яшел Үзән, Лениногорск, Чаллы, Түбән Кама, Нурлат, Чистай) һәм 8 район карамагындагы (Әгерҗе, Арча, Болгар, Лаеш, Мамадыш, Менделеев, Минзәлә, Тәтеш) шәһәр бар. Респ-када шәһәрләр, халык саныннан чыгып, кечкенә шәһәрләргә — халык саны 50 мең кешегә кадәр (Әгерҗе, Азнакай, Арча, Баулы, Болгар, Буа, Зәй, Лаеш, Мамадыш, Менделеев, Минзәлә, Нурлат, Тәтеш), уртача шәһәрләргә — 50 меңнән 100 мең кешегә кадәр (Бөгелмә, Алабуга, Яшел Үзән, Лениногорск, Чистай), зур шәһәрләргә — 100 меңнән 250 мең кешегә кадәр (Әлмәт, Түбән Кама), иң зур шәһәрләргә — 500 мең кешедән артык (Чаллы) — бүленә. ТР башкаласы Казанда миллионнан артык кеше яши. Респ-када шәһәр тибындагы 18 посёлок: Аксубай, Актүбә, Алексеев, Апас, Балтач, Байлар Сабасы, Васильево, Җәлил, Кама Аланы, Кама Тамагы, Карабаш, Куйбышев Затоны, Кукмара, Карамалы Тау, Түбән Мактама, Балык Бистәсе, Тенеш, Урыссу һәм 3 меңнән артык авыл торак пункты (авыллар, посёлоклар һ.б.) бар.

* ТАССР һәм ТР районнарының 1930, 1948, 1963, 1966, 2010 еллардагы исемлеген к. *Кушымтадан*.

**Халкы**. 2015 ел башына халык саны 3855 мең кеше тәшкил итә, ш.и. шәһәр халкы — 2939,7 мең (76,3%), авыл халкы — 915,3 мең кеше (23,7%). Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*$^2$ *га* 56,6 кеше. Респ-ка халык саны буенча Россиядә (Мәскәү, С.-Петербург шәһәрләреннән, Краснодар крае, Башкортстан Респ-касы, Мәскәү, Свердловск, Ростов өлкәләреннән кала) 8 нче урынны, Идел буе Федераль округында 2 нче урынны били. 1993–2010 елларда респ-када халык саны, туучылар аз, үлүчеләр күбрәк булу сәбәпле, табигый кими; халык саны мигрантлар күбәю исәбенә арта. 2000–05 тә күчеп килүчеләрнең артуы халыкның табигый кимүен өлешчә генә каплый (к. *Халык миграциясе*). 2011 дән туучылар саны үлүчеләр санынннан арта башлый. 2014 тә 56480 бала туа (1000 кешегә — 14,7 туучы), 46921 кеше үлә (1000 кешегә — 12,2 үлүче), халыкның табигый артуы 9559 кеше (1000 кешегә 2,5 кеше туры килә) тәшкил итә.

Халык составында, аеруча өлкән яшьтәгеләр арасында (71,1%), хатын-кызлар күбрәк (53,7%). Көтелгән уртача *гомер озынлыгы*: ирләрнеке — 66,4, хатын-кызларныкы — 77,7 яшь. 2014 тә халыкның 18,2% ын — балалар, 58,6% ын — эш яшендәгеләр, 23,2% ын өлкән яшьтәгеләр тәшкил итә. 2013 тә икътисад өлкәсендә 1817,7 мең кеше (хезмәт ресурсларының 75% ы), шуларның 22% ы — сәнәгать өлкәсендә; 17,6% ы — мәгариф, сәламәтлекне саклау, социаль, коммуналь һ.б. хезмәтләрдә; 17,1% ы — күмәртәле һәм ваклап сатуда, автотранспорт һәм көнкүреш чараларын ремонтлауда; 9,7% ы — урман һәм а.х.нда; 10,6% ы — төзелештә; 6,8% ы — транспорт һәм элемтәдә; халыкның 16,2% ы башка төр эшчәнлек б-н мәшгуль. Икътисад өлкәсендә эшләүчеләрнең 32% ы — югары һөнәри, 39,9% ы — башлангыч һәм урта һөнәри, 25,4% ы гомуми урта белемгә ия.

Татарстан — Россиядәге иң күп милләтле төбәкләрнең берсе. 2010 елгы Бөтенроссия халык санын алу мәгълүматларына караганда, респ-када 100 дән артык милләт яши, ш.и. 8 милләт халкының саны 10 мең кешедән арта (татарлар — 2 млн.нан артык, яки респ-ка халкының 53,2% ын тәшкил итә; руслар — 1,5 млн.нан артык яки 39,7%; чуашлар — 116,2 мең яки 3,1%; удмуртлар — 0,6%; мордвалар — 0,5%; марилар — 0,5%; украиннар — 0,5%; башкортлар — 0,3%).

**Дин.** Хәзерге Татарстан терр-ясендә беренче дин — Аллаһның берлеген тануга нигезләнгән *ислам* дине була. Ул Идел буе Болгар дәүләтендә 922 елда рәсми рәвештә кабул ителә. 980 елларның 2 нче яртысында Киев Русенда «дин сайлау» барышында Болгар идарәчеләре Бөек кенәз Владимирны ислам кабул итәргә күндерергә тырышып карыйлар, ләкин Владимир, боярлар һәм монахлар б-н киңәшкәч, христиан диненә өстенлек бирә. 990 да Владимир, халыкны православие диненә тарту өчен, Болгарга православие миссионерларын җибәрә, ләкин бу омтылыш та уңышсыз була. Казан төбәгендә православие 1550 елларның 2 нче яртысыннан гына — Казан ханлыгы яулангannan соң һәм аның җирләрен күчеп килүче руслар тарафыннан колонияләштерү барышында киң тарала башлый. 1920 гә ТАССРда 1200 гә якын мөселман мәхәлләсе һәм 650 православие приходы, 50 дән артык иске дин тарафдарлары җәмгыяте була; Казанда синагога, католик һәм лютеран чиркәүләре эшли.

1920 еллардан совет хакимиятенең сәясәте динне тамырдан корыту һәм атеизм тәрбияләү була. 1929–37 дә дин әһелләренә каршы репрессияләр киң җәелә, храмнар ябыла; 1940 ка кадәр ТАССРда нибары 5 мәчет һәм 2 православие чиркәве эшли. Бөек Ватан сугышы чорында дәүләтнең дини оешмаларга мөнәсәбәте яхшыра, 1944–48 дә 20 мәчет, 18 православие, 2 иске дин тарафдарлары, 1 яһүд һәм 2 протестант җәмгыятьләре үзләренең эшләрен яңадан башлый. 1950 еллар ахырында — 1960 еллар башында дингә каршы кампаниянең яңа дулкыны нәтиҗәсендә дини оешмаларның саны кабат кими һәм бары тик 1980 елларның 1 нче яртысында гына алар беркадәр күбәя. 1990 елларда сәясәтнең дингә карата мөнәсәбәте тамырдан үзгәрә, вөҗдан ирege игълан ителә, күп җирләрдә иске храмнарны дини җәмгыятьләргә кире кайтару һәм яңаларын төзү башлана.

2015 нең 1 гыйнварына ТРда 1483 мөселман мәхәлләсе, 286 православие, 69 протестант (11 номинация), 5 иске дин тарафдарлары (Рус православиесенең иске дин тарафдарлары чиркәвенә һәм Иске Поморье агымына карый), 1 католик, 3 яһүд һәм 10 башка дин приходы теркәлә. ТРда мөселман җәмгыятьләре *Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте* җитәкчелегендә, православие динендәгеләр Рус православие чиркәвенең Казан метрополиясе (к. *Казан епархиясе*) җитәкчелегендә берләшә. Казан *Рус православиесенең иске дин тарафдарлары чиркәвенең Казан-Вятка епархиясе* үзәге булып тора. Шәһәрдә *Россия ислам университеты*, 9 мәдрәсә, *Казан рухани лар семинариясе* эшли. Респ-када яшәүче мөселманнар хәнәфиләр мәзһәбе сөнниләренә карый. ТРда татарларның 6–8 % ын православие динендәге керәшен татарлар тәшкил итә. Русларның иң зур күпчелеге

*1 нче таблица*

1926–2010 елларда Татарстан Республикасы халкының милли составы**

| | 1926 | | 1939 | | 1959 | | 1979 | | 1989 | | 2002 | | 2010 | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Милләтләр | мең кеше | % | мең кеше | % | мең кеше | % | мең кеше | % | мең кеше | % | мең кеше | % | мең кеше | % |
| Барлык халык, | 2587,5 | 100,0 | 2914,2 | 100,0 | 2850,4 | 100,0 | 3445,4 | 100,0 | 3641,7 | 100,0 | 3779,3 | 100,0 | 3786,5 | 100,0 |
| ш.и. татарлар | 1263,3 | 48,7 | 1419,4 | 48,7 | 1345,2 | 47,2 | 1641,6 | 47,6 | 1765,4 | 48,5 | 2000,1 | 52,9 | 2012,6 | 53,2 |
| руслар | 1118,8 | 43,1 | 1251,3 | 42,9 | 1252,4 | 43,9 | 1516,0 | 44,0 | 1575,4 | 43,3 | 1492,6 | 39,5 | 1501,4 | 39,7 |
| чуашлар | 127,3 | 4,9 | 139,4 | 4,8 | 143,6 | 5,0 | 147,1 | 4,3 | 134,2 | 3,7 | 126,5 | 3,4 | 116,3 | 3,1 |
| украиннар | 3,1 | 0,1 | 13,1 | 0,4 | 16,1 | 0,6 | 28,6 | 0,8 | 32,8 | 0,9 | 24,0 | 0,6 | 18,2 | 0,5 |
| мордвалар | 35,1 | 1,4 | 35,5 | 1,2 | 32,9 | 1,1 | 29,9 | 0,9 | 28,9 | 0,8 | 23,7 | 0,6 | 19,2 | 0,5 |
| удмуртлар | 23,9 | 0,9 | 26,0 | 0,9 | 22,6 | 0,8 | 25,3 | 0,7 | 24,8 | 0,7 | 24,2 | 0,7 | 23,5 | 0,6 |
| марилар | 13,1 | 0,5 | 14,0 | 0,5 | 13,5 | 0,5 | 16,8 | 0,5 | 19,4 | 0,5 | 18,8 | 0,5 | 18,8 | 0,5 |
| башкортлар | 1,8 | 0,1 | – | – | 2,1 | 0,1 | 9,2 | 0,3 | 19,1 | 0,5 | 14,9 | 0,4 | 13,7 | 0,3 |

** Халык санын алу мәгълүматлары буенча; 1970 елга кадәрге мәгълүматларда — гомуми кеше саны, 1979, 1989, 2002 һәм 2010 елларда даими яшәүчеләр саны китерелә.

православие динен тота, зур булмаган өлеше — иске дин тарафдарлары. Татарстанда яшәүче мордва халкы тулысынча, чуаш һәм удмуртларның төп өлеше, мариларның 50 % ка якыны православие динен тота. Татарстанның көнчыгышында яшәүче марилар, көньягындагы һәм көньяк-көнчыгышындагы чуашлар һәм ш.у. Әгерҗе, Кукмара р-ннарында яшәүче удмуртлар арасында мәҗүсилек киң таралган.

## II. ФИЗИК-ГЕОГРАФИК ОЧЕРК

Республика Көнчыгыш Европа тигезлегенең көнчыгышында, Иделнең урта һәм Каманың түбән агымында, урман һәм урман-дала зоналарында, 53°58'–56°40' төньяк киңлек һәм 47°15'–54°18' көнчыгыш озынлык чикләрендә урнашкан. Терр-ясенең озынлыгы төньяктан көньякка — 290 *км*, көнбатыштан көнчыгышка — 460 *км*. Елга үзәннәре б-н физик-геогр. районнарга бүленә: Кама алды (Камадан төньякка һәм Иделдән төньяк-көнчыгыштарак), Кама аръягы (Камадан көньяктарак), Идел алды (Иделдән көнбатыштарак). Терр-я куе челтәрле елга үзәннәре, сызалар һәм ерымнар б-н бүлгәләнгән калкулыклы тигезлектән гыйбарәт. Уртача биеклеге 170 *м* чамасы, иң биек урын — 381 *м* (*Бөгелмә яссы калкулыгы*), иң тәбәнәк урын — 53 *м* (Куйбышев сусаклагычы өлеше). Кама алды — күбесенчә 170–200 *м* биеклектәге (иң биек өлеше 220–235 *м*) сөзәк калкулыклы тигезлек, төньяк-көнбатышында *Вятка увалының* көньяк итәге җәелгән. Кама аръягы Шушма елгасы үзәне б-н көнчыгыш һәм көнбатыш өлешләргә бүленә. Көнчыгыш Кама аръягы иң югары рельефы б-н характерлана, көньяк көнчыгышында *Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгының* төньяк-көнбатыш өлеше урнашкан, анда 200–300 *м* лы биеклекләр өстенлек итә, бүлгәләнү тирәнлеге 200 *м* га җитә. Көнбатыш Кама аръягында *Идел аръягы түбәнлегенең* (140–160 *м*) төньяк өлеше урнашкан. Көнчыгыш Кама алды һәм Көнчыгыш Кама аръягы калкулыклары арасында Каманың сул ярында озынлыгы (170 *м* га кадәр) һәм төзелеше буенча Көнбатыш Кама аръягы түбәнлегенә охшаш, әмма мәйданы буенча кимрәк булган Кама-Агыйдел түбәнлеге урнашкан. Идел алды исә *Идел буе калкулыгының* төньяк-көнчыгыш өлешен (өстенлек итүче биеклекләр 180–220 *м*, макс. биеклеге 276 *м*) тәшкил итә. Калкулык Иделгә таба бүлгәләнгән сөзәклекләр (аларның күбесе «таулар» дип йөртелә: Ослан, Сөйки, Тәтеш һ.б.) б-н текә яр ясап төшә. Кама һәм Иделнең сульяк ярлары буйлап елгаларның башка катламнарыннан хасил булган 10–15 *км* га кадәр киңлектәге террасалар җәелгән. Татарстан рельефының гомуми үзенчәлеге булып *геологик төзелеш* б-н ачык бәйләнеше һәм елга үзәннәре һәм субүләрләрнең ачык чагылган *сөзәклекләр асимметриясе* тора. Рельефның эре формалары — саналган калкулыклар һәм түбәнлекләр җир кабыгының яңа хәрәкәтләре нәтиҗәсендә хасил булганнар. Алар эрозия, карст, сөзәклек, эол, яр ясалу һәм эчке геодинамиканың башка процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән кечерәк формадагы комплекслары б-н катлауланган.

ТР терр-ясенең төп өлеше Пермь утырмаларыннан тора. Уфа ярусы утырмалары (калынлыгы 100–140 *м* га кадәр) респ-каның көнчыгышында Кама, Туйма, Иж, Ык елгалары үзәнлекләрендә юка катламлы мергель, известьташ һәм доломитлар б-н аралашкан кызгылт-көрән төстәге ком-балчыклар б-н ачыла. Респ-каның көнбатышында Казан ярусын доломит, гипс катламлы линзалы известьташлар, көнчыгышында кызгылт төстәге ком-балчык катламнары тәшкил итә (төньяк-көнчыгышта катламнарның калынлыгы 280 *м* га җитә). Татар бүлеге токымнары күбесенчә континенталь ком, алеврит һәм балчык катламнарыннан гыйбарәт; алар Идел алдының, Көнбатыш Кама алдының күп өлешен, Көнбатыш Кама аръягының шактый өлешен (көнбатышта калынлыгы 200 *м* га кадәр) төзиләр. ТРның көньяк-көнбатышында мезозой эратемасы — юра һәм акбур утырмалары урын алган. Юра утырмалары сай сулы диңгез шартларында хасил булган, составы соры һәм карасу-соры төстәге балчык, ком, алевритлардан һәм янучан сланецлар, фосфоритлы конгломератлар катнашкан мергельләрдән гыйбарәт (көньякта калынлыгы — 80 *м* га кадәр). Акбур утырмалары ш.у. диңгез шартларында хасил булган, түбән акбур утырмаларында (калынлыгы ерак көньяк-көнбатышта 160 *м* га кадәр) юка фосфоритлы соры һәм карасу-соры балчык чыганаклары, югары акбур катламнарында (көньякта 50 *м* га кадәр) аксыл-соры мергель һәм яза торган көпшәк акбур, фосфоритлар билгеле. Идел, Кама елгаларының һәм кушылдыкларының башка үзәнлекләренә, урыны б-н көнбатыш Кама аръягындагы түбән субүләрләргә елгадан хасил булган неоген системасы утырмалары (плиоцен) туры килә. Кисемнең урта өлешендә диңгез фаунасы калдыклары очрый, әлеге күренеш Каспий суларының башка үзәннәргә дә үтеп керүен раслый (Акчагыл трансгрессиясе). Бөтен җирдә дүртенчел система утырмалары, нигездә, тугай һәм тугай өсте террасаларын формалаштыручы аллювиаль кушылмалар үсеш алган (Идел һәм Кама елгалары үзәннәрендә катламнарның калынлыгы 80–120 *м* га кадәр). Елга үзәнлеге сөзәклекләрендә салкын бозлык климаты шартларында формалашкан балчыксыл делювиаль-солифлюкцион катламнар үсеш алган. Тау токымнары катламнарының яту урыны тектоник төзелеш б-н билгеләнә. ТР терр-ясе Рус платформасы нигезенең зур күтәрелеше булган Идел-Урал антеклизасы чикләрендә урнашкан. Антеклизаның көнбатыш өлешендә *Токмово гөмбәзе* аерылып тора, аның төньяк-көнчыгыш сөзәклеге респ-каның көнбатыш өлешен уратып алган. Терр-янең шактый өлешен *Төньяк Татар гөмбәзе* һәм Көньяк Татар гөмбәзе тәшкил итә, аларны бер-берсеннән тар һәм бик тирән булмаган *Зәй-Сарайлы бөгелеше* бүлә. Токмово гөмбәзен Төньяк Татар гөмбәзеннән тирән *Казан-Киров бөгелеше* (иңкүлеге), ә Көньяк Татар гөмбәзеннән *Мәләкәс батынкылыгы* аера. *Кристаллик нигездә* (тирәнлеге 1560 *м* дан да түбәнрәк) ятучы утырма тышлыгы чикләрендә кечкенә үлчәмле тектоник структуралар — вал һәм гөмбәзләр (алар углеводород чыганаклары б-н бәйле) аерылып тора. Кристаллик нигез түбәнлекләрендә (авлакогеннарда) төньяк-көнчыгышта, көньяк-көнбатышта һәм көньякта *венд* һәм *рифейның* башка утырма-вулканоген катламнары киң таралган, аларда девон катламнары урнашкан.

Респ-ка төрле *файдалы казылмаларга* бай. Аларның иң әһәмиятлеләре — ***нефть*** һәм иярчен газ. Беренче сәнәгый нефть чыганагы (Шөгер, 1973 елдан *Ромашкино нефть чыганагы* составында) 1943 нең июнендә ачыла, 1946 ның сентябреннән башлап нефть чыгарыла. 1957 дә респ-ка нефть чыгару буенча илдә беренче урынга чыга һәм 17 ел дәвамында шул урынны тота. 1972 дә — 1 нче, 1981 дә — 2 нче, 2007 дә 3 нче млрд. *т* нефть чыгарыла. Нефть чыгару барышында 100 млрд. $м^3$ дан күбрәк иярчен газ табыла. Өч меңгә якын традицион, битумлы һәм сланецлы ятманы үз эченә алучы 200 дән артык нефть чыганагы ачыла. Иң зурлары — Ромашкино, Яңа Елховой, Баулы, Беренче Май, Бондюг, Алабуга, Сабанчы чыганаклары девонның терриген утырмалары б-н бәйле (тирәнлеге 1,5–2 *км*, ачыкланган нефть запасларының 80% тан артыграк өлеше тупланган). Аларга составында 17–48% сумалалы матдәләр, 3,5–5,1% парафиннар, 0,4–1,8 % күкертле кушылмалар, бензин фракцияләре, җиңел һәм хуш исле углеводородлар булган җиңел нефть хас. 1 *т* нефть б-н бергә 40–70 $м^3$ иярчен газ да алына. Ачыкланган барлык нефть ятмаларының якынча өчтән бере 0,8–1,3 *км* тирәнлектә яткан түбән карбонның терриген катламнарында тупланган. Аларда нефть авыррак һәм югары күкертле. ТРда нефтьнең калдык сәнәгый запаслары 0,9 млрд. *т* тәшкил итә, алдан билгеләнгән запаслар — 0,1 млрд. *т*, фаразланган ресурслар — 1 млрд. *т*.

Түбән һәм урта Пермь, югары ташкүмер утырмаларына респ-каның көньягында һәм көньяк-көнчыгышында урнашкан 540 *м* га кадәр тирәнлектәге табигый битумнар ятмалары туры килә. Аларны, углеводород нигездән тыш, башка файдалы компонентлар (ванадий, никель, уран һ.б.) да булган авыр, югары үзлелекле нефть тәшкил итә.

Дүрт битумлы Пермь һәм югары ташкүмер комплексында табигый битумнарның 450 ятмасы ачыкланган. Фаразланган ресурслары 2 млрд.тан 7 млрд. *т* га кадәр бәяләнә. Иң эреләре — Мордва Карамалысы, Әшәлче, Түбән Карамалы чыганаклары. Хәзерге вакытта табу технологиясенең катлаулылыгы аркасында чыганаклар эшкәртелми, ә Әшәлчедә һәм Мордва Карамалысында сәнәгый битум алына. Пермь комплексы б-н битумлы токымнар да бәйле, алар өслектә ятулары (0–50 *м*), югары үзлелекләре һәм каты битумнар күләменең азлыгы (1–6 %) б-н аерылалар. 7 чыганакның ресурслары якынча 12 млн. $м^3$ тәшкил итә. Алар юл төзелешендә кулланыла, төзелеш материаллары ясау өчен файдаланылырга мөмкин.

Татарстанның җылылык-энергетика ресурсларына ташкүмер һәм көрән күмер



(к. *Казылма күмерләр*), ш.у. янучан сланецлар керә. Күмернең эре чыганаклары (ресурслары 2,7 млрд. *т*) көнчыгыш районнарда табылган, 880–1440 *м* га кадәр тирәнлектә булганлыктан, аларны сәнәгый эшкәртү туктап тора. Янучан сланецлар респ-каның көньяк-көнбатышында югары Юра утырмаларында ачыкланган, киләчәктә алар сәнәгый әһәмияткә ия булыр, аерым алганда сланецлы нефть алу өчен файдаланылыр, дип фаразлана.


Руда булмаган файдалы казылмалардан төзелеш, тау-техник һәм агрохимик чимал запаслары бар. Зур елга үзәннәре утырмалары б-н комлы-гравийлы материал чыганаклары бәйле. Аларның зур сәнәгый әһәмияткә ия булган эрерәкләре Кама елгасы үзәнендә урнашкан (Чаллы сәнәгый төзелеш зонасы). 2015 ел башына 70 чыганак тикшерелгән, сәнәгый чимал запасы якынча 260 млн. $м^3$ тәшкил итә. Идел, Кама һәм аларның кушылдыкларының аллювиаль утырмаларына төзелеш комнары чыганаклары туры килә. Дүртенчел, күбрәк делювиаль-солифлюкцион утырмаларда, балчык чималы запаслары бар, алар керамик кирпеч һәм чирәп җитештерү өчен файдаланыла. Кирпеч-чирәп чималының 91 чыганагы ачыкланган (сәнәгый запаслары — 158,7 млн. $м^3$). Югары Пермь известьташ һәм доломитлар чагылмаларына 77 төзелеш ташлары чыганагы туры килә (80 млн. $м^3$). Иделнең уңъяк ярында Казан ярусы утырмаларында 2 сәнәгый гипс чыганагы (Кама Тамагы һәм Сөйки) табыла, гомуми запасы — 63 млн. *т*. Тау-техник чималларга форма ясарга яраклы һәм бораулау балчык порошоклары, керамзит җитештерү өчен файдаланыла торган бентонит балчыклары керә (Тукай, Түбән Кама һәм Нурлат р-ннары терр-ясендә сәнәгый запасы 45 млн. *т* булган 3 чыганак ачыклана). Агрохимик чималны фосфоритлар (1 чыганак; 224 мең *т*), ш.у. карбонат токымнары (40 чыганак; 90,2 млн. *т*) билгели, алар ачы туфракны известьләү өчен кулланыла.

Татарстанның ***климаты*** уртача континенталь, җәен җылы һәм кышын уртача салкын. Уртача алганда бер елга кояш балкышы дәвамлылыгы 2000 *сәг.* чамасы, төньяк-көнбатышта 1880–1910 *сәг.*, төньяк-көнчыгышта 2050 *сәг.*кә кадәр дәвам итә (чагыштырыр өчен: Мурманск шәһәрендә 1292 *сәг.*, Мәскәүдә — 1723, Сочида — 2177 *сәг.*); апрельдән августка кадәр кояшлы чор булып исәпләнә. *Кояш радиациясенең* горизонталь өслеккә уртача айлык төшү күләме (*МДж/м²*) түбәндәгечә: июньдә — 374 (туры), 283 (сибелгән), 657 (гомуми), декабрьдә — 10, 32 һәм 42 *МДж/м²*. Гомуми радиациянең уртача еллык күләме 3900 *МДж/м²* га җитә. Уртача болытлы булганда, ноябрь–февральдә радиация балансы тискәре (–27 дән алып –46 *МДж/м²* га кадәр), калган вакытта уңай, июньдә аеруча югары (333 *МДж/м²*). Һава температурасын билгеләүдә төп фактор булып ***атмосфера циркуляциясе*** тора. Елның салкын вакытында ТР терр-ясе Атлантика (Исландия минимумы) һәм Себер (Азия максимумы) йогынтысына бәйле, Көнбатыштан Көнчыгышка таба темп-ра төшүгә сәбәпче була. Җылы вакытта циркуляция процесслары көчсезләнә, җылы режим формалашуда радиацион факторлар һәм җирле шартларның роле арта. Респ-ка терр-ясенә уртача киңлекләрдән диңгез һавасы үтеп керәп, һава торышын тотрыксыз, явым-төшемле итә, шул сәбәпле язын һәм җәен бераз салкынай-







1. Идел елгасы Зөя елгасы тамагы янында. Югары Ослан районы; 2. Кама елгасы Алабуга шәһәре янында; 3. Вятка елгасы Мамадыш шәһәре янында; 4. Ил елгасы; 5. Раифа күле. Яшел Үзән районы; 6. Бирге Кабан б-н Аргы Кабан күлләре арасындагы ермак; 7. Карабаш сусаклагычы. Карабаш тавыннан күренеше. Бөгелмә районы; 8. Чишмә. Азнакай районы.














1. Көнчыгыш Кама аръягы. Типик ландшафт; 2. Куаклы наратлык. Кукмара районы; 3. Ылыслы урман. Саба районы; 4. Ык елгасы үзәне күренеше. Азнакай районы; 5. Идел-Кама саклаулыгы. Раифа участогы; 6. Идел алды. Типик ландшафт.

та, ә көзен һәм кышын сизелерлек җылыта. Арктик һава массаларының керүе еш кына төньяк һәм төньяк-көнбатыш, кайвакыт төньяк-көнчыгыш ташкыннары б-н бәйле, шуның нәтиҗәсендә кинәт салкынайта, язын һәм көзен кырау төшә. Көньяктан һәм Көньяк-Көнбатыштан (җәй көне ш.у. көньяк-көнчыгыштан) тропик һава килә, кышын җылытуга (җепшек көннәр) һәм җәен эсселеккә (кайвакыт коры җилле көннәр) сәбәп була. Кышын Себердән уртача киңлекләрдән салкын континенталь һава үтеп керә һәм аз болытлы салкын көннәргә китерә. Һаваның уртача еллык темп-расы (1966–2004 еллар мәгълүматларына карагандa) 3,2 °С тан (Бөгелмә) 4,1 °С ка кадәр (Казан) үзгәрә. Соңгы 100 елда ул якынча 0,6 °С ка арткан. Елның иң салкын ае — гыйнвар (һаваның уртача темп-расы –12,4 °С), иң җылы ай — июль (темп-ра 19,5 °С). Абс. минимумнар –47–52 °С ка, абс. максимумнар 37–40 °С ка җитә. Уртача тәүлеклек темп-раның 0 °С аша тотрыклы күчеше язын апрельнең 1 нче декадасында, көзен октябрь ахырында була. Терр-ядә җылы чор (0°С тан югары тотрыклы темп-ра) 198–209 көн чамасы дәвам итә. Һавада кыраулар бетү вакыты уртача 7–25 майга, туфракта — 19 май—6 июньгә; беренче көзге кыраулар төшү вакыты тиңдәшле рәвештә 7–29 сентябрьгә һәм 3–18 сентябрьгә туры килә. Җил режимы барик-циркуляцион процессларның сезонлы үзенчәлекләре б-н билгеләнә. Сентябрьдән алып апрельгә кадәр һәм, гомумән, ел буена Көньяк һәм Көньяк-Көнбатыштан искән җилләр өстенлек итә, җәйге чорда горизонтның төньяк-көнбатыш чирегендәге җилләр кабатлануы күзәтелә. Бик көчле җилләр салкын чорда билгеләнә. *Атмосфера явым-төшемнәренең* уртача еллык күләме 460–540 *мм* чикләрендә тирбәлә; аларның 60–70% ы җылы чорда (апр.–окт.) ява. Явым-төшемнәр бүленешенә җирнең рельефы сизелерлек тәэсир итә. Идел алды, Кама алды, Көньяк-Көнчыгыш Кама аръягы дымлырак, Көнбатыш Кама аръягы аз дымлы. Гомумән, ТР терр-ясе дымлылык җитәрлек булмаган зонада, чөнки явым-төшемнәр күләме парга әйләнүчәнлектән кимрәк (538–635 *мм*). Кар капламы октябрьнең 3 нче декадасында ята, апрельнең 2 нче декадасында эреп бетә. Тотрыклы кар капламы ноябрьнең 2 нче декадасы ахыры — 3 нче декадасы башында (аерым елларда октябрь ахырыннан алып декабрьнең 3 нче декадасына кадәр) барлыкка килә. Кар ятуның уртача дәвамлылыгы — 140–150 көн, биеклеге — ачык урыннарда 35–45 *см*, ышык урыннарда 50–75 *см*, су запасы 100–150 *мм* тәшкил итә. Кышын туфрак туңа. Туңның иң зур тирәнлеге март аена туры килә һәм ул уртача 74–114 *см* (38–74 тән 110–165 *см* га кадәр) тәшкил итә. Атмосфера циркуляциясе процессларының үзенчәлекләре Татарстан терр-ясендәге томан төшү (елга уртача 16–46 көн), бураннар (24–58 көн, окт.– апр.), яшен (25–30 көн, апр.–сент.), боз яву (елга 1–2 көн, күбрәк май–июнь айларында), корылык (уртача 3–4 елга 1 тапкыр), тузан өермәләренә сәбәп була.

Респ-ка *су ресурсларына* бай. Су өслегенең мәйданы 4,4 мең $км^2$ (барлык терр-янең 6,4%). Елгалар челтәре яхшы үсеш алган: аларның уртача тыгызлыгы 0,37, иң зуры 0,48 $км/км^2$ (Көнчыгыш Кама алды). Иң зур елгалар (озынлыгы 500 *км* дан артык) — *Идел*, *Кама*, *Вятка*, *Агыйдел*, алар респ-ка терр-ясеннән читтә башланып китәләр. 20 елганың озынлыгы (Ык, Зөя, Олы Чирмешән, Иж, Дала Зәе, Чишмә, Мишә, Кече Чирмешән, Гөбенә, Минзәлә, Казансу һ.б.) 100 дән алып 500 *км* га кадәр. Елгаларның күбесе су җыелу мәйданы 2 мең $км^2$ га кадәр һәм озынлыгы 100 *км* дан азрак булган кечкенә елгалар категориясенә керә. Еллык су җыелуның 60–80% ын кар сулары тәэмин итә, көчле язгы ташулар шуның б-н аңлатыла (мартның соңгы көннәрендә башлана, май башында тәмамлана). 8 меңнән артык *күл* (башлыча элекке елга юлында һәм карст убылулары нәтиҗәсендә барлыкка киләләр) исәпләнә. Аларның иң зурлары — *Кабан күлләре*, *Тирән күл*, *Раифа күле*, *Архиерей күле*, *Кавал күле* — Идел елгасының сулъяк яр террасаларында. Пермь сульфат-карбонат токымнарыннан көчле басымлы сулары б-н туенучы *Олы Зәңгәр күл* һәм *Кече Зәңгәр күл* уникаль күлләр булып исәпләнә. Җир өсте суларының төп запаслары сусаклагычларда тупланган. Аларның иң зурлары — *Куйбышев сусаклагычы* (күләме 56 $км^3$, Татарстанда Идел буйлап һәм Кама буйлап Чаллы шәһәренә кадәр) һәм *Түбән Кама сусаклагычы* (2,8 $км^3$). Дала Зәе елгасында *Зәй сусаклагычы* (63 млн. $м^3$), Бөгелмә Зәе елгасында *Карабаш сусаклагычы* (52,4 млн. $м^3$) төзелгән. Кечкенә елгаларда, коры үзәннәрдә, чокырларда 500 ләп буа (файдаланыла торган гомуми су күләме 600 мең $м^3$ дан артык) ясалган. Респ-ка терр-ясендә 2 меңләп *сазлык* бар, алар бигрәк тә тугайларда, елгаларның түбән террасаларында, иң зурысы — *Көләгеш сазлыгы* (4900 *га*) Кама-Агыйдел түбәнлегендә. Җир асты суларының запасы шактый: көчле минеральләшкән сулар, тозлы һәм аз тозлы (төче) сулар; аларның бер өлеше дәвалау максатында файдаланыла (к. *«Бәкер»*, *«Иж минераль сулары»*).

Туфрак капламы төрле. Респ-ка терр-ясендә *соры урман туфраклары* (барлык




**Тайга зонасы хайваннары.** 1. Суер; 2. Озын койрыклы ябалак; 3. Чыршы чукыры; 4. Өч бармаклы тукран; 5. Байгыш; 6. Божыр; 7. Чукрак күке; 8. Эрбетче; 9. Очкалак тиен; 10. Чырайсыз ябалак; 11. Борындык; 12. Себер көзәне; 13. Гади кара елан; 14. Тереләй тудыручы кәлтә.

**Киң яфраклы урман хайваннары.** 15. Урман күгәрчене; 16. Гади төн күгәрчене; 17. Ак муенлы чебенче; 18. Тавышлы зур каракош; 19. Шәүлегән; 20. Көртлек кош; 21. Миләш чыпчыклары: а) миләш чыпчыгы, б) сайрар миләш чыпчыгы; 22. Елак карчыга; 23. Тәлләтәвеч; 24. Бакыр елан; 25. Буа бакасы; 26. Җирән кыр тычканы; 27. Бакча йонлачы; 28. Бурсык; 29. Бакыр кәлтә.




**Дала һәм урман-дала хайваннары.** 1. Дала каракошы; 2. Соры көртлек; 3. Таш чыпчыгы; 4. Зур шөлди; 5. Сары сиртмәкойрык; 6. Сабан тургае; 7. Кыр карчыгасы; 8. Дала торымтае; 9. Һөдһөд; 10. Гади җир бакасы; 11. Дала көзәне; 12. Яшел гөберле бака; 13. Гади кыр тычканы; 14. Зур кушаяк; 15. Гади әрлән; 16. Тимгелле йомран; 17. Дала кара еланы.
**Су һәм су яны хайваннары.** 18. Саескан-шөлди; 19. Яр чыпчыгы; 20. Кара крачка; 21. Яр песнәге; 22. Су тавыгы; 23. Бүрекле чумгалак; 24. Саз чомгасы; 25. Саз ташбакасы; 26. Кызыл корсаклы су «үгезе»; 27. Җәен; 28. Бёрш; 29. Чөгә балык; 30. Чуртан; 31. Елга керкәсе.




1:1 50

1 сантиметрд

15 0 15 30

Тоташ горизонтальләр 5





00 000

а 15 километр

45 60 75 90

50 метр саен үткәрелгән

Картаның текстлар өлеше ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институтында Гайнанова Ф.Г., Гарипова Ф.Г., Даутов Р.Н., Сабирҗанов Г.С. (җитәкче), Саттаров Г.Ф., Яруллина А.Г. катнашында эшләнде. Карта Роскартографиянең Урал картография фабрикасында 2002 елда басылды. Заказы 284 к.
2014 елда ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты тарафыннан өстәмәләр, төзәтүләр кертелде һәм басмага әзерләнде.




| карта-дагы № | Район исеме | Район үзәге исеме | карта-дагы № | Район исеме | Район үзәге исеме | карта-дагы № | Район исеме | Район үзәге исеме | карта-дагы № |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 38 | Азнакай | Азнакай ш. | 30 | Балык Бистәсе | Балык Бистәсе а. | 13 | Менделеев | Менделеев ш. | 18 |
| 35 | Аксубай | Аксубай штп | 43 | Баулы | Баулы ш. | 20 | Минзәлә | Минзәлә ш. | 31 |
| 21 | Актаныш | Актаныш а. | 15 | Биектау | Биектау пос. | 28 | Мөслим | Мөслим а. | 39 |
| 12 | Алабуга | Алабуга ш. | 41 | Бөгелмә | Бөгелмә ш. | 34 | Нурлат | Нурлат ш. | 25 |
| 24 | Алексеев | Алексеев штп | 30 | Буа | Буа ш. | 9 | Питрәч | Питрәч а. | 29 |
| 22 | Апас | Апас штп | 26 | Зәй | Зәй ш. | 7 | Саба | Байлар Сабасы а. | 15 |
| 2 | Арча | Арча ш. | 14 | Кайбыч | Олы Кайбыч а. | 27 | Сарман | Сарман а. | 42 |
| 5 | Әгерҗе | Әгерҗе ш. | 23 | Кама Тамагы | Кама Тамагы штп | 32 | Спас | Болгар ш. | 36 |
| 33 | Әлки | Базарлы Матак а. | 4 | Кукмара | Кукмара штп | 10 | Теләче | Теләче а. | 8 |
| 37 | Әлмәт | Әлмәт ш. | 16 | Лаеш | Лаеш ш. | 19 | Тукай | Чаллы ш. | |
| 1 | Әтнә | Олы Әтнә а. | 40 | Лениногорск | Лениногорск ш. | | | | |
| 3 | Балтач | Балтач штп | 11 | Мамадыш | Мамадыш ш. | | | | |

I Казан шәһәренең административ идарә территориясе
Административ-территориаль бүленеш 2010 елның гы

**1:1 50**

1 сантиметрда

15 0 15 30




| Район исеме | Район үзәге исеме |
| --- | --- |
| Түбән Кама | Түбән Кама ш. |
| Тәтеш | Тәтеш ш. |
| Чирмешән | Чирмешән а. |
| Чистай | Чистай ш. |
| Чүпрәле | Иске Чүпрәле а. |
| Югары Ослан | Югары Ослан а. |
| Ютазы | Уруссу штп |
| Яңа Чишмә | Яңа Чишмә а. |
| Яшел Үзән | Яшел Үзән ш. |

е
айнварына бирелгән

0 000

а 15 километр

45 60 75 90

Картаның текстлар өлеше ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институтында Гайнанова Ф.Г., Гарипова Ф.Г., Даутов Р.Н., Сабирҗанов Г.С. (җитәкче), Саттаров Г.Ф., Яруллина А.Г. катнашында эшләнде. Карта Роскартографиянең Урал картография фабрикасында 2002 елда басылды. Заказы 284 к.
2014 елда ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты тарафыннан өстәмәләр, төзәтүләр кертелде һәм басмага әзерләнде.

терр-янең 37% ы), *кара туфраклар* (32%), кәсле-көлсу (к. *Көлсу туфраклар*) һәм *кәсле-карбонатлы туфраклар* киң таралган. Елга үзәннәрендә — аллювиаль, *кара болын туфраклары* һәм сазлы туфрак. Урман зонасында урнашкан Кама алдында гумус запасы аз булган, әче реакцияле кәсле-көлсу һәм аксыл-соры төстәге ылыслы һәм ылыслы-яфраклы урман туфраклары күпчелекне тәшкил итә. Идел алды һәм Кама аръягы терр-яләренең күпчелек өлешенә, нигездә, лёссыман утырмаларда болын-дала үләннәре тәэсирендә формалашкан һәм составында гумусның шактый күп булуы б-н аерылып торган, уңайлы физик һәм физик-химик үзлекләргә ия уңдырышлы карасу-соры урман туфраклары һәм кара туфраклар хас.

Респ-ка терр-ясендә 124 семьялыкка, 578 ыругка караган 1610 төрдәге күп тамырлы үсемлекләр ачыкланган. Иң күп таралган семьялыклардан — *оешма чәчәклеләр* яки кашкарыйчалар (236 төр), йончалылар яки *кыяклылар* (149 төр), кузаклылар (93), *роза чәчәклеләр* (91), *күрәнчәләр* (83), *әвернә чәчәкләләр* (80), *канәферчәләр* (67), сыраҗчалар (59), баллутчалар яки *иренчәчәклеләр* (55), *чатырчәчәклеләр* (45), *казаякчалар* (39), алабутачалар (39), *карабодайчалар* (35). Алар урман, болын, дала, сазлык, басу бергәлекләре хасил итәләр. Урман үсемлекләренең саны 19 йөздә сизелерлек кыскарган, аның өлешенә ТР терр-ясенең 17,2% туры килә, урманнар урыны-урыны б-н һәм тигезсез урнашканнар (терр-янең урманлылыгы Нурлат р-нында 35% тан Чүпрәле р-нында 2,6% ка кадәр). Кама алдында чыршы һәм ак чыршы урманнары үсә, аларның да күп өлеше яфраклы агач токымнары б-н кушылган. Комлы һәм комсу елга үзәннәре террасаларына нарат урманнары хас. Киң яфраклы урманнар (имән, юкә, имән катыш юкә) терр-янең бөтен җирендә дә очрый, иң зур мәйданнары Кама аръягында. Идел алдына типик таулы имәнлекләр хас. Иделдән Көнчыгышка таба киң яфраклы урманнарда юкә өлеше арта. Ылыслы һәм киң яфраклы урманнарны кырып бетерү нәтиҗәсендә субүләрле урыннарда икенчел каен һәм усак урманнары үсеп чыккан. *Болыннар* икенчел барлыкка килгән һәм ТР терр-ясенең 15,5% били. Болын үсемлекләренең төп массиве ерым-сыза системаларында, болар — үрге (кашлак) яки материк болыннар, көтү йөртү өчен файдаланыла. Күбрәк тар яфраклы йонча, кызыл солыча, гади мeңьяфрак, гади әнис, болын яраны, зәһәр казаяк һ.б. үсә. Грунт сулары якын яткан сөзәклекләр итәгендә уйсу болыннар киң таралган (ак кырчыл, болын солысы, каз тәпие, шуышучы казаяк һ.б.). Көньяктагы текә сөзәклекләрдә далаланган болыннар (болын далалары), кылганлы һәм типчаклы болыннар урнашкан (аларга болын-далада үсә торган төрле үсемлекләр хас (каурыйсыман кылган, типчак, Альп кашкарые, Австрия песи борчагы, эре чәчәкле тәңкәяфрак һ.б.). Елга тугайларында төрле кыяклылар, төрле үләнле-кындыраклы, йончалы-кызыл солычалы болыннар очрый. Җирләрнең 70% ы сөрелгән, табигый үсемлекләр урынына культуралы үсемлекләр һәм чүп үләннәре үсә.

*Хайваннар дөньясында* тайга һәм киң яфраклы урманнар, дала, су яны һәм су хайваннары очрый. Умырткалыларның 470 ләп төре яши. Ихтиофаунада балыкның 55 төре: корбан балык, судак, чуртан, җәен, сазан, чабак, густера, кәлчәк, күк чабак (синец), берш һ.б., шулардан иң затлысы — чөгә балык. Җир-су хайваннарының 11 төре (гади һәм сырлач тритоннар, соры һәм яшел гөберле бака, кызыл корсаклы «су үгезе», сасы бака, күл бакасы, буа бакасы, ашарга яраклы бака, очлы башлы бака һәм үлән бакасы); сөйрәлүчеләрнең 8 төре (бакыр кәлтә, тереләй тудыручы кәлтә, җизбаш, гади тузбаш, соры тузбаш, гади кара елан, дала кара еланы, саз ташбакасы) яши. Орнитофауна 295 төр коштан (очып килгәннәрен исәпләмичә) гыйбарәт, шуларның 38% ы — чыпчыксыманнар, 19% ы шөлдисыманнар отрядына карый. Респ-ка терр-ясеннән 14 төр (сары башлы кәрлә тургай, бүрекле песнәк, кара песнәк, кычыткан чыпчыгы, чыршы чукыры, эрбет чыпчыгы, корыхтан, свиязь-үрдәк, гаршнеп-чуллык, саңгырау күке, карчыгасыман ябалак, йонтәс аяклы ябалак, кара тукран, өч бармаклы тукран) ареалының көньяк чиге, 5 төр (балобан, дала торымтае, саз көтүчесе, кечкенә чомга, йорт ябалагы) ареалының төньяк чиге, 2 төр (урман тургае, яшел күке) ареалының көнчыгыш чиге уза. Имезүчеләр төркеменең 6 отрядына (бөҗәк ашаучылар, кулканатлылар, ерткычлар, куштояклылар, кимерүчеләр, куянсыманнар) караган 75 төре керә. Шулардан 13 төр (кече актеш, Наттерер төп ярканаты, зур кичке ярканат, кәрлә ярканат, карсак, дала көзәне, җирән йомран, дала тычканы, зур кушаяк, соры әрлән, Эверсман әрләне, дала чуары, сукыр әрлән) ареалының төньяк чиге, 8 төр (көрән аю, селәүсен, төньяк күнканаты, очкалак тиен, борындык, бакча йоклачы, кызгылт кыр тычканы, урман тычканы) ареалының көньяк чиге, 6 төрдән дә ким булмаган (кече көрәнтеш, тимгелле йомран, зур йоклач, урман йоклачы һәм чикләвек йоклачы, кара күсе) ареалының көнчыгыш чиге уза. 20 йөз башында синантропизация процесслары көчәя, ягъни күп кенә хайваннар кеше янына, алар төзегән яки үзгәрткән ландшафтларга җайлашалар (яшел гөберле бака, җитез кәлтә, гади тузбаш, кыр үрдәге, күк күгәрчен, ала карга, кара карга, чәүкә, саесқан, зур песнәк, ак чәперчек, йорт чыпчыгы һәм кыр чыпчыгы, купшыл, карабүрек, гади керпе, коңгырт ярканат, соры күсе, йорт тычканы һ.б.).

Кешенең хуҗалык һ.б. эшчәнлеге флора һәм фаунага еш кына зыян китерә, моңдый хәлдән котылу өчен, махсус чаралар күрелә. Шул максатны күздә тотып, *аеруча саклаулы табигать территорияләре һәм акваторияләре* челтәре: Идел-Кама дәүләт табигый биосфера саклаулыгы (к. *Идел-Кама саклаулыгы*), *Түбән Кама* милли паркы, табигый саклаулыклар, табигать истәлекләре (ш.и. 33 күл һәм 30 елга) булдырыла. 2015 нең 1 гыйнварына ТРның табигый саклаулык фонды гомуми мәйданы 167,55 мең *га* (ТР мәйданының 2,47% ы) булган 171, ш.и. 126,84 мең *га* мәйданда төбәкара әһәмияткә ия 166 аеруча саклаулы табигать терр-яләрен берләштерә. ТРның Кызыл китабы (2 нче басма, 2006) чыгуын дәвам итә, аңа барлыгы 668 төр, шуларның 137 төре умырткалылар, ш.и. балыклар — 10, кошлар — 84, рептилияләр — 5, амфибияләр — 3, имезүчеләр — 34 төр; 109 төр умырткасыз хайваннар, 310 — югары төзелешле көпшәле үсемлекләр, 28 — мүк, 24 — лишайник, 40 — гөмбәләр, 20 төр суүсемнәр теркәлгән.

*Әд.:* Попов В.А., Лукин А.В. Животный мир Татарии. К., 1988; Аскеев И.В., Аскеев О.В., Беляев А.Н. Млекопитающие Республики Татарстан (конспект современного состояния фауны). К., 2002; Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003; Нефтегазоносность Республики Татарстан. Геология и разработка нефтяных месторождений: В 2 т. К., 2007; Климатические условия и ресурсы Республики Татарстан. К., 2008; Дедков А.П. Избранные труды. К., 2008; Рахимов И.И., Мосалов А.А. Птицы Республики Татарстан: Атлас-определитель. К., 2008.

## III. ТАРИХИ ОЧЕРК

Кешенең Урта Идел буе төбәгенә килеп урнашуы *таш гасырның* беренче дәвере — *палеолитка* туры килә. Хәзерге Татарстан терр-ясендә беренче кешеләр якынча 100–35 мең еллар элек пәйда була. Ул вакытта климат, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы хәзергедән шактый аерыла. Борынгы кешеләр хезмәт коралы итеп кителгән ташлар кулланганнар, ут таба, өс-баш киеме тегә һәм торак кора белгәннәр, ауга йөргәннәр, табигать җимешләрен җыйганнар (балыкчылык башлангыч хәлендә булган). Татарстан терр-ясендә шул чорга караган иң борынгы археол. истәлекләр — «Красная Глина» туктаулыгы һәм Идел елгасының уңъяк ярындагы (хәзерге Тәтеш р-ны) торулыклар. Моннан 10 мең еллар элек Көнчыгыш Европа тигезлеге терр-ясендә хәзерге типтагы климат урнаша. Бу исә төбәк халкының хуҗалык итү һәм көнкүреш рәвешенә шактый үзгәрешләр кертә; кешеләр тормышында ваграк җанварлар аулау беренче урынга чыга. Ау җайланмалары һәм кораллары камилләшә, соңгы палеолит дәверендә тора-бара төп коралга әверелгән җәя барлыкка килә. Торулыклар, гадәттә, елга буйларына, биек булмаган калкулыкларга һәм террасаларга урнаша, тораклар җиңел конструкцияле һәм кечкенә итеп салына. Татарстанда *мезолит* дәвере археол. культуралары — якынча б.э.к. 6 нчы меңьеллыкка караган *Чулман тамагы культурасы, Чулман буе культурасы* (Тәтеш ш., Кама Тамагы р-ның Сөйки Кичүе пос. янында һ.б.) истәлекләре билгеле.

*Неолит* дәверендә кешеләр балчык савыт-саба, бораулап тишеп, ялтыратып һәм башка техник ысуллар кулланып элеккегә караганда камилрәк таш хезмәт кораллары ясарга өйрәнгәннәр, эрләү һәм туку эшен үзләштергәннәр. Төп шөгыльләрен әүвәлгечә аучылык, табигать җимешләрен җыю, балыкчылык тәшкил иткән (терлек асрауга күчү башланган). Неолит дәверендә кешеләр учагы һәм хуҗалык чокырлары бер түбә астына урнаштырылган, яртылаш җиргә кертеп са-

лынган зур корылмаларда яшәгәннәр. Татарстан терр-ясендә неолит дәвереннән өч төркем — Чулман буе культурасы, *Балахна культурасы*, чәнчеп-сызып төшерелгән бизәкле керәч археол. истәлекләре сакланган.

Бронза гасырда (Татарстан терр-ясендә якынча б.э.к. 3 нче меңьеллыкның 2 нче яртысы — 2 нче меңьеллык), металл хезмәт һәм сугыш кораллары барлыкка килү б-н, борынгы кешеләрнең таралу ареалы шактый киңәя. Төбәккә терлекчелек б-н көн күрүче күчмә һәм ярымкүчмә кабиләләр үтеп керә (бу дәвергә караган археол. истәлекләр Татарстанның барлык терр-ясендә диярлек бар). Әлеге кабиләләр үз культураларын, йолаларын (мәс., курган өеп җирләү), җир өстендә торак кору алымнарын, керамика ясау, металл, сөяк, таш эшкәртүнең камилрәк ысулларын һ.б.ны алып килә. *Бураль курган культурасы* һәм *Баланово культурасы* кабиләләре төрле һөнәрләр үсешендә (мәс., металл кораллар — балталар, ук очлыклары, ш.у. беләзекләрне күпләп эшләү һ.б.) шактый уңышка ирешә. *Абашево культурасы, Казан яны культурасы* һәм *Чиркәскүл культурасыннан* сакланып калган истәлекләр бронза металлургиясенең алга киткән булуы турында сөйли. Шулай ук терлекчелек, иң гади игенчелек үсеш ала, җәмгыятьнең социаль структурасы катлауланa. Җитештерү эшчәнлегендә аерым һөнәр төрләре (металлургия, чүлмәкчелек эше һ.б.) аерылып чыга. Югары көчләргә ышануларның элгәрге төрләре: тотемизм, уңыш, кояш, ут культы һ.б. барлыкка килә.

Бронза гасырдан *тимер гасырга* күчү акрынлык б-н, башлыча, б.э.к. 2 нче меңьеллык ахыры — 1 нче меңьеллык башында бара. Тимерне үзләштерү бронза коюның куәтле үсеше б-н бергә дәвам итә. Татарстан терр-ясендә элгәрге тимер гасыр дәвере культурасы вәкилләрен фин-угор кабиләләре тәшкил итә. Тимер коюның үсеш алуы җирле кабиләләрнең хуҗалык эшчәнлегендә игенчелекнең роле артуга сәбәп була. *Ананьино культурасы* вәкилләре бронза эш коралларыннан да, тимер эш коралларыннан да файдаланалар. *Городец культурасы, Пьянобор культурасы, Мазунино культурасы, Азелино культурасы, Имәнкискә культурасы, Ломоватово культурасы, Кушнаренко культурасы* кабиләләре, яңа технол. алымнар кулланып, тагын да камилрәк тимер эш кораллары, игенчелек кирәк-ярагы ясый башлыйлар. Аларның яшәештә киң кулланылуы Урта Идел буе халкына б.э.ның 1 нче меңьеллыгында зур гына мәйданнарда урман төпләп чәчүлек җирләр ачу (төпләп яндыру игенчелек системасы), җир эшкәртүне камилләштерү, тораклар төзү һәм йөк ташу җайланмалары ясауда агач файдалану мөмкинлеге бирә; төрле һөнәрләрнең (аеруча тимерчелекнең) үсешен тизләтә, кабиләләр арасында товар алмашуны киңәйтә.

2–7 йөзләр — *Халыкларның бөек күченеше* чоры буларак билгеле дәвер. Урта Идел буе терр-ясенә төрки-угор кабиләләре килеп урнаша. Төбәкнең 6–8 йөзләрдә сан ягыннан арткан төрки телле халкы культурасы *Төрки каганлык, Хәзәр каганлыгы, Бөек Болгар дәүләте* культурасына якын тора. 7 йөздә Бөек Болгар дәүләте хәзәрләр тарафыннан яулана, һәм болгарларның бер өлеше Урта Идел буена күчеп утыра. 10 йөздә алар бирегә беренче дәүләт — *Идел буе Болгар дәүләтен* төзиләр. Дәүләт дине — ислам (922 елда кабул ителә). Шул вакыттан болгар халкының рухи тормышы Көнчыгыш илләренең мөселман культурасы йогынтысында үсә. 13 йөз башына Идел буе Болгары игенчелек, терлекчелек, шәһәрләр төзелеше, һөнәрчелек һәм сәүдә ягыннан алга киткән ил булып җитешә. *Биләр, Болгар, Җүкәтау, Суар* һ.б. шәһәрләр һөнәрчелек житештерүе һәм сәүдә үзәгенә әверелә. Идел буе Болгар дәүләтенең югары матди һәм рухи мәдәнияте Идел һәм Урал буе халыкларының көнкүрешенә һәм тормыш рәвешенә сизелерлек йогынты ясый (к. *Болгар мәдәнияте, Болгар теле*). Якын күршеләр һәм ерак илләр б-н тыгыз сәүдә элемтәләре, мәдәни һәм сәяси мөнәсәбәтләр урнаштырыла.

1236–37 дә монголлар басып керү Идел буе Болгар дәүләте тарихында борылыш чоры була (к. *Идел буе Болгар дәүләтенә монгол яулары*). *Батый хан* гаскәрләре тарафыннан буйсындырылганнан соң, ул *Алтын Урда* составындагы берничә биләмәгә (әмирлеккә) таркала (к. *Болгар бәклеге, Җүкәтау бәклеге, Казан бәклеге, Кашан бәклеге*). Алтын Урда хакимлеге дәверендә төрки телле халыкларның этник-мәдәни яктан берләшүе барышында татар халкы формалаша (к. *Татарлар*). Болгар, Җүкәтау, Казан, Кашан, Иске Казан шәһәрләре адм. хакимият, һөнәрчелек, сәүдә, мәдәни һәм дини тормыш үзәкләренә әверелә. Алтын Урдада бертуктаусыз барган үзара сугышлар (14 йөзнең 2 нче яртысы — 15 йөзнең 1 нче яртысы) дәүләтне әчтән какшата һәм аның таркалуына китерә (1502). Урда терр-ясендә берничә татар дәүләте барлыкка килә: *Казан ханлыгы, Себер ханлыгы, Нугай Урдасы, Кырым ханлыгы, Әстерхан ханлыгы.*

1438–45 тә Казан ханлыгы оеша. Ханлык адм. яктан 5 даругага: *Алат даругасы, Арча даругасы, Галич (Гәреч) даругасы, Җөри даругасы, Нугай даругасына* бүленә, анда 700 дән артык торак пункт булуы мәгълүм. Казан, Алат, Арча, Болгар, Иске Казан, Кашан, Лаеш, Тәтеш, Чаллы шәһәрләрендә тимер кою, корал ясау, чүлмәкчелек, зәркәнчелек, тире, агач эшкәртү һәм башка һөнәрчелек җитештерүе төрләре туплана. Дәүләт тормышында Русь, Урта Азия һәм Кавказ илләре б-н алып барылган сәүдә-икътисади мөнәсәбәтләр зур роль уйный (мех, тире эшләнмәләр, бал, икмәк чыгарыла; тукымалар, терлек, зиннәтле әйберләр, затлы корал, аш тәмләткечләр һ.б. кертелә). Сәүдәгәрләр атавы (к. *«Маркиз» утравы*), *Арча кыры, Ташаяк* Казанның атаклы сәүдә итү урыннары булып китә.

Казан ханлыгы Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урда этник-мәдәни һәм социаль-икътисади традицияләрен мирас итеп ала. Ханлык терр-ясендә Идел-Урал буе татарларының этнос булып формалашуы тәгәлләнә: телнең җирле диалектик үзенчәлекләре акрынлап җуела, гомумтатар тел нормалары гамәлгә керә. «Идел буе төрки теле» гомуми таралыш ала, рәсми эш кәгазьләре, шул тел нигезендә язма дипломатия элемтәләре алып барыла, әдәбият һәм тарих гыйлеме үсә. Әлеге чордан бүгенге көнгә килеп җиткән татар әдәби әсәрләреннән аеруча танылганнары — *Мөхәммәдьярның* «Төхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге», 1539–40) һәм «Нуры содур» («Күңелләр нуры», 1542) поэмалары, *Колшәриф* шигырьләре һ.б. Ханлыкта мәдрәсә-мәктәпләр челтәре киң җәелдерелә, балалар дин нигезләрен өйрәнәләр, уку-язуны үзләштерәләр (тормыш кирәк-яракларында, кабер ташларында сакланган язулар халыкта мәгърифәтнең киң таралган булуы турында сөйли). Ташка уеп бизәк төшерү эше алга китә (осталар кабер ташларын шул рәвешле бизиләр). Язма чыганаклар, халык авыз иҗаты мәгълүматларына караганда һәм археол. истәлекләр исбатлаганча, төзү эше һәм архит-ра ш.у. югары үсешкә ирешә (к. *Даир мунчасы, Колшәриф мәчете, Нурали мәчете, Бизәлеш сәнгате, Гамәли-бизәлеш сәнгате, Татар халык архитектурасы, Татар халык сәнгате.*

Казан ханлыгы оешканнан башлап, аның тышкы сәясәтендә төп юнәлешне көчәя баручы Рус дәүләте б-н мөнәсәбәтләр тәшкил итә. Ханлык тарихы тулысынча алар арасында өзлексез дип әйтерлек барган сугышлардан тора. Дәүләтнең башлангыч чорында Казан ханнары Мәскәүнең хәрби-сәяси экспансиясенә уңышлы каршы торалар. Әмма 1487 дә Мәскәү кенәзе Иван III Казанга яу б-н килгәннән соң, Казан ханлыгы өстеннән *Мәскәү протектораты* (1487–1521) урнаштырыла. Җирле аксөякләр күп тапкырлар Мәскәүгә бәйлелектән котылу омтылышы ясап карыйлар; 1521 елгы чираттагы түнтәрелештән соң, Казан тәхетенә Кырым ханы *Сәхибгәрәй* чакырыла, Кырым партиясенең хакимлек дәвере башлана. 1540–50 елларда Рус дәүләте, Казан аксөякләренең үзара көрәшүеннән һәм хан хакимлеге какшаудан файдаланып, Казан ханлыгына яулап алу һөҗүмнәре оештыра башлый (к. *Казанга Рус дәүләтенең яулары*). *Иван IV Грозныйның* Казанга яулары барышында, 1551 дә, Идел кушылдыгы Зөя елгасы тамагында Зөя кальгасы торгызыла, бу Мәскәү хөкүмәтенә ныгытма тирәсендәге төбәкләр (Тау ягы һ.б.) халкын буйсындыру мөмкинлеге бирә. Мәскәү б-н Казан арасында Идел сәүдә юлында һәм Идел-Урал төбәгендә хакимлек итү өчен туктаусыз барган көрәш 1552 нең 2 октябрендә 49 көнлек камалыштан соң Казанны рус гаскәрләре алуы б-н тәгәлләнә (к. *Казанның яулап алынуы*). Казан ханлыгы яшәүдән туктый, төбәк б-н идарә итү эше *Казан сарай идарәханәсенә* тапшырыла. Ханлыкның төп халкы берничә ел буена рус идарәчелегенә каршы аяусыз көрәшә (к. *Казан җирләрендә азатлык сугышлары*).

Казан ханлыгы Рус дәүләте тарафыннан яулаганнан соң, татарлар Казаннан, зур елга һәм олы юл буена урнашкан авыллардан куыла. Бары тик *йомышлы татарларның* ке-

черәк бер төркемәнә Казанда алар өчен махсус билгеләнгән бистәгә күчәргә рөхсәт бирелә (к. *Иске Татар бистәсе*). Шул ук вакытта рус хөкүмәте ханлык җирләренә рус крәстияннәренең, ш.и. качак крепостной крәстияннәрнең дә килеп утыруын хуплый: төбәк терр-ясенә русларның күпләп күченүе башлана; төп халыкларның таркатылган авыллары урынында рус ныгытма-шәһәрләре: Арча, Козьмодемьянск, Лаеш, Тәтеш, Чабаксар, Цивильск һ.б. барлыкка килә (к. *Колонияләштерү*). Рус булмаган халыкларны мәдәни ассимиляцияләү максатыннан, Казан ханлыгын буйсындыру б-н Иван IV Грозный хөкүмәте һәм православие чиркәве христианлаштыру сәясәте үткәрергә керешә. 1555 тә *Казан епархиясе* оештырыла. Чиркәүләр һәм монастырьлар төзелә башлый. Иван IV тарафыннан Казанның беренче архиепископы Гурийга христианлаштыруны тормышка ашыру буенча күрсәтмәләр бирелә (к. *Иван IV нең Казан архиепископы Гурийга җибәргән күрсәтмәсе*, 1555). Православие чиркәве Казан төбәге б-н идарә итү органнарының берсенә әверелә һәм дөньяви хакимият эшләренә катнашу хокукы ала. Икътисади һәм адм. кысулар, көчләп чукындыру сәясәте 16–17 йөзләрдә *татарлар һиҗрәтен* китереп чыгара: татар халкының байтак өлеше Чулман аръягы һәм Урал буендагы яңа җирләргә күченергә мәҗбүр була. Бу исә игенчелек, терлекчелек, һөнәрчелек, сәүдә кебек хуҗалык алып бару традицияләрендә өзеклекләр тудыра. Татарларга металл кою, тимерчелек эше һәм металл эшкәртү, металл эшләнмәләр ясау б-н бәйле башка төр җитештерү эшчәнлеге тыела (к. *Тыелган товарлар*). Казан ханлыгында гамәлдә булган тархан һәм сөйургал җирбиләүчелеге (к. *Тархан, Сөйургал*) патша сарае, чиркәү-монастырь, биләмә хуҗасы идарәсендәге җирбиләүчелек төрләре б-н алыштырыла (к. *Патша сарае крәстияннәре, Монастырь крәстияннәре, Алпавыт крәстияннәре*). Элекке ханлыкның төп халкы *ясаклыларга* әверелә; татар феодалларының бер өлеше Рус дәүләтенең йомышлылар катлавына кертелә.

*«Болгавыр заман»* елларында (16 йөз ахыры — 17 йөз башы) Казан төбәге гамәлдә Мәскәүдән һәм күрше-тирә шәһәрләрдән аерымлана. Аның терр-ясен кузгалышлар чолгап ала (к. *Казан ханлыгы яуланганнан соңгы фетнә-чуалышлар*). Воевода В.П.Морозов җитәкчелегендәге Казан гаскәре поляк баскынчыларына каршы оештырылган беренче ополчениегә кушыла (1611). Казан феодал башлыкларының бер өлеше (Н.М.*Шульгин* һ.б.) чыгышлары б-н руслардан булган җирле феодаллар хакимлеге астында аерым дәүләт төзү фикерен күтәреп чыга. Казанда сәяси фетнә Михаил Фёдорович Романов патша булып сайланганчы (1613) дәвам итә. Дини һәм милли изү, ш.у. туктаусыз арта барган дәүләти һәм феодаль салымнар төбәк халкының социаль-икътисади һәм мәдәни үсешендә каршылыклар тудыра, фетнә һәм күтәрелешләргә сәбәп була (*Җангали хәрәкәте*, *Крәстияннәр кузгалышы (1670–71*).

18 йөзнең 1 нче чирегендә Казан төбәге үсешенә *Пётр I нең* социаль-икътисади һәм сәяси үзгәртеп корулары сизелерлек йогынты ясый. 1708 дә *Казан губернасы* төзелә, аның составына Урта Идел буе һәм Көнбатыш Урал җирләре кертелә. Казан Россия империясенең иң мөһим адм. һәм сәнәгать үзәкләренең берсенә әверелә. *Казан постау мануфактурасы, Казан адмиралтействосы, Помпа каеш-күннәре заводы* оешу б-н мануфактура җитештерүе киңәя. Тиз арада вак товар җитештерүе һәм сәүдә алга китә. Халыкның социаль структурасында да үзгәрешләр барлыкка килә: рус булмаган халыклар, башлыча татарлар арасыннан Россия хәрби-диңгез кораблары төзелеше өчен урман кисү, агач әзерләү һәм чыгару йөкләмәсен үтәүче лашманнар категориясе формалаша; хөкүмәт реформалары барышында аерым катлау — *дәүләт крәстияннәре* катлавы оештырыла (Казан губернасында 18 йөз ахырында ясаклылардан, йомышлы татарлар, экономик крәстияннәр, авыл халкының башка категорияләреннән туплана).

Пётр I һәм аның варислары идарә иткән дәвердә рус булмаган халыкларны христианлаштыруның яңа чоры башлана (к. *Татарлар турында Россия кануннары*), аны тормышка ашыру өчен махсус учреждение — *Яңа чукындырылганнар конторасы* булдырыла (1731). Миссионерлар тарафыннан үткәрелгән мәҗбүри чаралар нәтиҗәсендә 18 йөз уртасына чуаш, мари, мордва һәм удмуртларның күпчелек өлеше христианлыкка күчә (татарлар, нигездә, ислам диненә тугры кала). Көчләп чукындыру төбәк халыкларының *Крәстияннәр кузгалышында (1773–75)* актив катнашуы сәбәпләренең берсе булып тора. Татарларның христианлаштыру сәясәтенә карата аяусыз каршылык күрсәтүе патша хөкүмәтен бу мәсьәләдә ташламалар ясарга мәҗбүр итә. Изге Синодның «Барлык диннәргә карата түземлелек турында» («О терпимости всех вероисповеданий...», 1773) фәрманы нигезендә православие чиркәвенә ислам дине һәм христиан булмаган башка конфессияләр эшенә тыгылу тыела; 1784 тә татар морзаларының хокуклары рус дворяннарының хокуклары б-н тигезләштерелә). 1781 дә Казан татар бистәләре үзидарәсе органы — *Казан шәһәре татар бистәләре ратушасы* оештырыла, ул Казандагы татар җәмәгатьчелеген, сәүдәгәрлек һәм сәүдә капиталын берләштерүдә зур роль уйный. Империячел сәясәтнең беркадәр йомшавы мәчетләр һәм мәчет каршында эшләүче мәктәп-мәдрәсәләр челтәре киңәюгә, көчләп чукындырылганнарның массакүләм рәвештә кабат мөселманлыкка кайтуына мөмкинлек ача (к. *Чукындырылган татарларның мөселманлыкка кайту хәрәкәте*).

Капиталистик мөнәсәбәтләр үсеше, милли буржуазия барлыкка килү 18–19 йөзләр чигендә татар халкының социаль-икътисади тормышындагы үзгәрешләр *татар мәгърифәтчелеге* туугга һәм таралыш алуга нигез булып тора. Мәгърифәтчелек идеяләре илаһият галиме һәм дин эшлеклесе Г.Курсави, шагыйрь Утыз Имәни хезмәтләрендә һәм әсәрләрендә чагылыш таба. Татар мәгърифәтчелек фикеренең иң югары үсешкә ирешкән чоры 19 йөзнең 2 нче яртысына туры килә һәм гомерләрен мәгарифне үстерү һәм фәнни гыйлемнәр таратуга, дини катып калганлыкка һәм милли чикләнгәнлеккә каршы көрәшкә багышлаган Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Х.Фәезханов һ.б.ның эшчәнлеге б-н бәйле була.

19 йөз башында төбәк халыклары Наполеон явына каршы көрәшкә кушылалар (к. *Ватан сугышы*); Казан губернасында халыктан җыелган хәйрия акчасына *Казан ополчениесе* оештырыла; ополчение Россия армиясенең Польша, Силезия, Богемия, Саксония терр-яләрендәге походларында катнаша.

19 йөзнең 1 нче яртысында Казан губернасының социаль-икътисади тормышында иң әһәмиятле мәсьәләләреннән берсе — крәстияннәр мәсьәләсе була. Дәүләт авылы реформасына (1837–41) җавап итеп, Козьмодемьянск, Цивильск, Чабаксар һәм Ядрин өязләрендә крәстиян кузгалышлары була (к. *Әкрам авылы кузгалышы*). *Крәстиян реформасын* (1861) тормышка ашыру барышында крәстияннәрнең яңа кузгалышлары башлана (к. *Бизнә крәстияннәре кузгалышы*), алар гаскәрләр тарафыннан бастырыла.

19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башындагы хөкүмәт реформалары илдә буржуаз мөнәсәбәтләр үсешен тизләтү өчен шартлар тудыра (к. *Капитализм, Буржуазия*). Индустрияләштерү процессы Казан губернасы сәнәгатен дә иңләп ала: мануфактурага алмашка завод-фабрика җитештерүе килә. Сәнәгатьтәге үзгәртеп корулар җиңел һәм химия сәнәгатендә аеруча киң колач б-н бара (Казанда А.А.Алафузовның җитен эрләү-туку ф-касы һәм күн з-ды, бертуган Крестовниковларның сабын кайнату з-ды заманча җиһазлар б-н тәэмин ителгән була). 1884 тә Казан шәһәрендә генә фабрика-завод тибындагы 91 пр-тие исәпләнә. Шулай да Россиянең үзәк районнары б-н чагыштырганда, төбәкнең сәнәгый үсеше акрынрак бара: 1860 елларда сәнәгать продукциясе җитештерү буенча губерна 14 нче урынны били. 19 йөздә банк капиталы үсеш ала. Казанда бер үк вакытта диярлек *Казан шәһәр җәмәгать банкы, Сәүдәгәрләр банкы,* Дәүләт банкының Казан бүлеге, *Дворяннар җир банкының Казан бүлеге, Крәстияннәр җир банкының Казан бүлеге* һ.б. ачыла. 19–20 йөзләр чигендә җитештерүнең концентрациясе һәм аның банк капиталы б-н кушылуы күзәтелә. Төбәктә төрле төрдәге күпсанлы акц. җәмгыятьләре барлыкка килә («Иван Стахеев һәм К°», «Әхмәтҗан Сәйдәшев угыллары белән һәм Бакый Субаев» һ.б.). Сәнәгать үсеше авыл халкын шәһәрләргә тартып китерә, чималга һәм азык-төлеккә ихтыяҗ арта, бу исә а.х.ның товарлылыгын күтәрә һәм крәстияннәрнең катлауларга аерылу процессын көчәйтә. Реформалар милли сәнәгать үсеше өчен уңай шартлар тудыра. Татар җәмәгатьчелегендә буржуаз мөнәсәбәтләр ныгу һәм үз араларыннан яңа элита оешып калку халыкның милли үзаңы үсүгә һәм яңа идеология — *җәдитчелек* хәрәкәте барлыкка килүгә этәргеч бирә.

Дөньяви милли әдәбият, тарихи фәннәр, татар вакытлы матбугаты һәм проф. сәхнә сәнгате җәдитчеләрнең мәдәният һәм мәгърифәтне үстерү идеяләре нигезендә формалаша. Татар буржуазиясе актив хәйриячелек эшчәнлеге алып бара, милли мәгарифкә акчалата булышлык итә. 19–20 йөзләр чигендә татар халкының милләт буларак формалашуы тәмамлана.

19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында, төбәкнең төп халыкларын көчләп христианлаштыру сәясәтеннән формаль рәвештә баш тартуына карамастан, патша хөкүмәте бу юнәлештә чаралар үткәрүдән туктамый. Рус православие чиркәве тарафыннан Урта Идел һәм Урал буеның рус булмаган халыклары арасында алып барылган миссионерлык эшчәнлеген нәтиҗәлерәк итү максатыннан, әҗнәбиләр өчен ачылган барлык христиан мәктәпләрендә махсус укыту системасы кертелә (к. *Ильминский системасы*); бу мәктәпләргә укытучы-миссионерлар әзерләү өчен 1864 тә — Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе, 1872 дә — Казан рус-әҗнәби укытучылар семинариясе, 1876 да Казан татар укытучылар мәктәбе ачыла. *Изге Гурий борадәрлегенең* миссионерлык мәктәпләре б-н беррәттән, губернада министрлык карамагындагы *рус-татар училищеләре* һәм мәдрәсә-мәктәпләрдә рус сыйныфларын ачу башлана. Шул ук вакытта ислам дине әһелләренең пед. эшчәнлеген чикләү һәм җәдиди мәктәпләрнең уку-укыту программаларын кыскарту бара (к. *Александр III Фәрманы* (1888 ел, 16 июнь).

1905 елның язы һәм җәендә Казан губернасын эшчеләр күтәрелеше һәм крәстияннәр кузгалышы чорнап ала (к. *Россиядә 1905–07 еллар революциясе*). Демократик хокуклар һәм ирекләр турындагы 1905 елның 17 октябрь Манифесты губернада төрле *сәяси партияләр, иҗтимагый-сәяси оешмалар һәм хәрәкәтләр* барлыкка килүне активлаштыра, ш.у. эшчеләр һәм хезмәткәрләр *профсоюзлары* төзелә. 1906–07 дә губернадагы иҗтимагый-сәяси тормышның төп вакыйгасы 1 нче һәм 2 нче Дәүләт Думасына сайлаулар була (к. *Дәүләт Думасы*). Рев-ция милли мәдәният һәм татар халкының этносәяси үзаңы үсешенә, милли тигезлек һәм демократик ирекләр өчен көрәш хәрәкәтенә көчле этәргеч бирә. Татарлар катнашында узган съездларда һәм җыелышларда Россиянең мөселман халыкларына иҗтимагый-сәяси ирекләр, дини конфессия идарәсендә, милли мәгариф, мәдәният һәм тел мәсьәләләрен хәл итүдә тулы мөстәкыйльлек бирү таләпләре куелган резолюцияләр кабул ителә (к. *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары*). Әлеге таләпләр беренче гомуммөселман партиясе *«Иттифакъ әл-мөслимин»*нең программасына нигез итеп алына. Татар яшьләре катнашында иҗтимагый-сәяси оешмалар һәм әдәби түгәрәкләр төзелә, вәкиллекле форумнар уздырыла (к. *Шәкертләр хәрәкәте*). *«Казан мөхбире», «Йолдыз», «Азат», «Азат халык», «Таң йолдызы»* һ.б. г-талар чыга башлый. Әмма рев-ция барышында Россия җәмгыятендәге сәяси, социаль-икътисади һәм милли проблемалар хәл ителмәгән килеш кала, башланган үзгәртеп корулар туктала. *Столыпинның аграр реформасы* ш.у. җир мәсьәләсен хәл итми, авылдагы социаль киеренкелекне йомшарта алмый.


Рев-ция җиңелгәннән һәм илдә авторитар-полиция режимы урнашканнан соң, 1907 нең җәеннән рев-ция вакыйгаларында катнашканнарны сәяси эзәрлекләүләр башлана, әлеге вазгыять радикаль оппозиция вәкилләренә дә, милли һәм дини хәрәкәт җитәкчеләренә дә кагыла. Татар иҗтимагый-сәяси һәм дин эшлеклеләреннән дистәләгән кеше (Г.Г.*Апанаев*, Һ.М.*Атласов*, Г.М.*Баруди*, Г.Б.*Вәисов* һ.б.) эзәрлекләнүгә һәм кулга алынуга дучар ителә. Милли мәгариф системасын, милли мәдәният һәм әдәбиятны үстерүгә юнәлдерелгән һәртөрле омтылыш илнең идарәче даирәләре тарафыннан Россиянең дәүләтчелек нигезләрен какшатуга тиңләп карала (к. *Панисламизм, Пантюркизм*). 1917 нең 17 октябрь Манифесты игълан иткән вөҗдан иреге керәшен татарларның православиедән мөселманлыкка күчүенең яңа дулкынын кузгата. Моңа җавап итеп, хөкүмәт тарафыннан мөселман дини мәктәпләренә кагылышлы яңа чикләү кагыйдәләре кертелә («Шәркый әҗнәбиләр мәгарифенә багышланган махсус киңәшмә», С.-Петербург, 1905). Төбәктәге башка халыкларны татарларның этномәдәни йогынтысыннан аралау чаралары эшләү максаты б-н 1910 ның гыйнварында Россия хөкүмәте тарафыннан *«Идел буе төбәгендә мөселман татарлар йогынтысына каршы чаралар билгеләүче махсус киңәшмә»* чакырыла. Киңәшмә тәкъдимнәре исәпкә алынып, татар милли хәрәкәтенең, вакытлы матбугатының һ.б. актив эшлеклеләренә карата җәза чаралары күрелә. 1910 да Казан губернасында 97 җәдиди мәктәп ябыла, 1911 дә, хәрби көчләргә таянып, «Буби» мәдрәсәсе тар-мар ителә (к. *«Бубилар» эше*).

*Беренче бөтендөнья сугышы* елларында Казан губернасы гаскәрләрне сугышчылар һәм сугыш кирәк-яраклары б-н тәэмин итүче гомумроссия тыл базаларының берсенә әверелә (к. *Казан хәрби округы*). 1914–17 дә Россия армиясенә губернадан 290 мең кеше мобилизацияләнә. 1915 нең җәендә төбәккә качаклар килә башлый (60 мең тирәсе кеше эвакуацияләнә), ш.у. хәрби әсирләр кайтарыла (беренче төркем — 1013 кеше — 1914 нең декабрендә кабул ителә). Россия империясенең көнбатыш төбәкләреннән Казанга төрле оешмалар һәм сәнәгать пр-тиеләре эвакуацияләнә. Күп кенә сәнәгать пр-тиеләре хәрби продукция җитештерүне үзләштерә: Казандагы 43 завод һәм фабрика (15,5 мең кеше) фронт ихтыяҗларын үти. Эшче куллар кимү, йөк атлары һәм җигүле терлек саны кыскару, а.х. инвентаре тузу һәм башка сәбәпләр б-н сугыш чорында чәчүлек мәйданнар кечерәя, бөртекleләр уңышы кими (1 дисәтинәгә 50 поттан — 30 потка кадәр). Халык кулланучы товарлары җитештерүче пр-тиеләргә чимал һәм ягулык җитешмәгәнлектән, тормыш өчен иң кирәкле товарлар б-н тәэмин ителеш начарая. Болар исә губернада социаль киеренкелекне көчәйтә: шәһәрләрдә һәм авылларда сугышка, хөкүмәткә каршы чыгышлар ешая.

*Февраль революциясеннән* (1917) соң Казан губернасында иҗтимагый-сәяси тормыш активлаша. Сәяси амнистия игълан ителү б-н, илдәге социаль партияләр легаль рәвештә эшли башлый, либераль партияләр үз эшчәнлекләрен тергезә, иҗтимагый-сәяси көрәшкә яңа оешмалар — *Казан хәрби округы комитеты, Казан мөселман социалистлар комитеты, «Җәмәгать иминлеге комитетлары»* һ.б. кушыла. Губерна хакимияте тамырдан үзгәртелә: губернатор урынына Вакытлы хөкүмәт комиссары билгеләнә, Эшче һәм солдат депутатлары советы оеша, ул да идарә эшендә катнаша. Гамәлдә икевластьлылык урнаша. Татар халкының иҗтимагый-сәяси тормышы ш.у. активлаша. Бөтенроссия мөселманнары корылтайларында барлык Россия халыкларының сәяси, гражданлык һәм дини тигезлеге, Россия мөселманнарының иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни ихтыяҗлар нигезендә берләшү зарурлыгы, ш.у. булачак төрки-татар дәүләтчелеге турында резолюцияләр кабул ителә. Бу карарларны тормышка ашыру өчен милли үзидарә органнары — *Милли Идарә, Бөтенроссия мөселманнарының Милли Шурасы* (Милли Шура), *Бөтенроссия мөселманнарының хәрби шурасы* төзелә, төрки-татарларның беренче милли парламенты — *Милләт Мәҗлесе* сайлана. 1917 нең 22 июлендә, Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең беренче корылтае, Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтае һәм Бөтенроссия мөселман руханилары корылтаеның уртак утырышында Эчке Россия һәм Себер төрки-татарларының Милли-мәдәни мохтарияты (автономиясе) турында Декларация кабул ителә, *Милли-мәдәни мохтарият нигезләрен эшләү комиссиясе* оештырыла.

1917 нең октябрендә хакимияткә большевиклар килә (к. *Казанда 1917 елгы Октябрь коралль баш күтәрелеше*). Алар тарафыннан Россия халыкларының тигезлеге һәм ирекле үзбилгеләнү хокукы турында лозунг игълан ителә. Милли демократик көчләр элекке Россия империясендәге милли-дәүләти корылыш барышында татарлар һәм башкортларның *Идел-Урал Штаты* рәвешендәге дәүләтчелеген төзергә ниятлиләр. Булачак дәүләт составына Казан, Уфа губерналары, Вятка, Оренбург, Пермь, Самара, Сембер губерналарының бер өлеше керергә тиеш була. Әмма бу план үзәк хакимиятнең кискен каршылыгына очрый (к. *Болак арты республикасы*); аңа каршы буларак, 1918 нең мартында *Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасы* төзү турында карар кабул ителә (проект тормышка ашырылмый кала). Большевиклар һәм аларга дошман сәяси көчләр каршылыгы Россиядә *Гражданнар сугышы* (1917–22) башлануга китерә. Казан губернасы терр-ясе аяусыз сугыш хәрәкәтләре эчендә кала, Кызыл Армиянең *Көнчыгыш фронты* гаскәрләре *Учредительләр җыены Комитеты әгъзаларының* (КОМУЧ) *Халык армиясе*, Чех-словак корпусы (к. *Чех-словак корпусы фетнәсе*), адмирал А.В.*Колчак* ар-


ТОРАК ПУНКТЛАР
КАЗАН Республика башкалалары, губерна үзәкләре
БУА Кантон, өяз үзәкләре
Яңгул Волость үзәкләре
Андреевка Башка торак пунктлар
ЧИК СЫЗЫКЛАРЫ
1921 елның апреленә республика, өлкә, губерна чикләре
1921 елның апреленә Татарстан АССР кантоннары чикләре
2010 елда Татарстан Республикасы
ЮЛЛАР
Тимер юллар
Төп юллар (трактлар)
Башка юллар
Татарстан АССР кантоннары:
1 Арча
2 Зөя
3 Лаеш
4 Мамадыш
5 Алабуга
6 Буа
7 Тәтеш
8 Спас
9 Чистай
10 Минзәлә
11 Бөгелмә
1921 елның апреленә Татарстан АССР составында булмаган волостьлар:
1 Чепья
2 Киртәле
Искәрмә: Алабуга кантоны рәсми рәвештә 1921 елның июнендә оештырыла.
МАРИ АВТОНОМИЯЛЕ ӨЛКӘСЕ
ВЯТКА
ЧУАШ АВТОНОМИЯЛЕ ӨЛКӘСЕ
СЕМБЕР ГУБЕРНАСЫ
САМАРА
КАЗАН
АРЧА
ЗӨЯ
ЛАЕШ
БУА
ТӘТЕШ
СПАС
ЦИВИЛЬСК
СЕМБЕР
МӘЛӘКӘС
ИДЕЛ
КАМА
50°
55°
56°
1:1 50
1 сантиметрда
15 0 15 30




00 000

а 15 километр

45 60 75 90

Карта «ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты» дәүләт учреждениесе тарафыннан 2010 елда төзелә. Төзүдә 1:420000 масштаблы Татарстан Совет Социалистик Республикасы картасы (Казан дәүләт нәшрияты, 1921 ел) файдаланыла.

миясе частьлары б-н сугыша. Татар халкының бер өлеше милли хәрби берләшмәләр составында (к. *Беренче аерым Идел буе татар укчылары бригадасы, Икенче аерым Идел буе татар укчылары бригадасы*) совет хакимиятен яклап көрәшә. Гражданнар сугышы чорында губерна икътисады таркалу хәленә килә. Большевиклар үткәргән *«хәрби коммунизм»* сәясәте җәмгыять б-н идарә итүдә хәрби тәртипләр урнаштыру, әмер биреп эшләтү, сәнәгатьне национализацияләү (к. *Национализацияләү*); җирдән хосусый файдалануны юкка чыгару; азык-төлек һәм чимал тартып алу (к. *Продразвёрстка*), төп азык-төлек һәм сәнәгать продукциясен, сыйнфый принциптан чыгып, дәүләт оешмалары тарафыннан бүлдерү (карточка системасы), гомуми хезмәт йөкләмәсе үтәү һ.б. чараларда чагылыш таба. Болар һәммәсе икътисади һәм сәяси кризис китереп чыгара, *ачлык* (1921–22 еллар) башлану сәбәпләренең берсе була (2 млн.нан артык кеше ачлыкка дучар ителә, Татарстанда халык саны 400–600 меңгә кими), киң җәмәгатьчелектә, аеруча крәстиян катлавында кискен канәгатьсезлек тудыра (30 га якын төбәктә зур чуалышлар куба; к. *«Сәнәкчеләр» фетнәсе*). «Хәрби коммунизм» сәясәтенең нәтиҗәсезлеге большевиклар хакимиятен аннан баш тартырга һәм 1921 нең мартыннан базар икътисады һәм шәхси эшмәкәрлек принципларына нигезләнгән *Яңа икътисади сәясәткә (НЭП)* күчәргә мәҗбүр итә.

1920 нең маенда татар халкының милли автономиясе мәсьәләсе кабат күтәрелә; РКП(б) ҮК Политбюросының махсус утырышында Татарстан АССРны оештыру турындагы декрет проектын эшләү Комиссиясе төзелә. 1920 нең 27 маенда РСФСРның БҮБК һәм ХКС тарафыннан әзерләнгән *«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы турында» Декретка* кул куела. 1920 нең 25 июнендә Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советының Казан губерна башкарма ком-ты хакимиятне *Вакытлы революцион комитетка (ВРК)* тапшыра. 1920 нең июль–август айларында ВРК *Татарстан АССР Советларының беренче (оештыру) съездын* чакыруга әзерлек эшләре алып бара. Съезд 1920 нең 26–27 сентябрендә Казанда уза. Съездда 59 кешедән торган ТАССР ҮБК сайлана (Г.Б.Баһаветдинов, А.И.Догадов, К.Х.Исмаев, Б.Х.Мансуров, К.Г.Мохтаров, С.С.Сәетгалиев, М.Х.Солтангалиев һ.б.). 28 сентябрьдә *Татарстан АССР Үзәк Башкарма комитетының беренче пленар утырышында* хөкүмәт — ТАССР ХКС төзелә (рәис — С.С.Сәетгалиев, әгъзалар — Ю.Н.Вәлидов, А.В.Гордеев, А.И.Догадов, Г.Й.Измайлов, А.С.Изюмов, В.Исхаков, К.Г.Мохтаров, А.Н.Нехотяев, М.Г.Рошаль һ.б.), ТАССР ҮБК Президиумы сайлана (рәис — Б.Х.Мансуров, әгъзалар — Х.З.Гайнуллин, А.А.Денисов, А.Копнов, А.С.Самохвалов, А.П.Таняев, Н.Я.Яруллин). 1925 нең 25 июнендә, ТАССР ҮБКның 2 нче сессиясендә ТАССР Конституциясе проекты кабул ителә. Ул 1926 ның 13 мартында, ТАССР Советларының 6 нчы съездында карала һәм хуплана, әмма БҮБК, Бөтенроссия Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советлары съезды тарафыннан расланмый; шулай да ул татар дәүләтчелеге формалашу процессына җитди йогынты ясый (к. *Татарстан Республикасы Конституциясе*).

Татарстан АССР оешу һәм чагыштырмача мөстәкыйль дәүләт идарәсе системасы төзелү б-н, 1920 елларда респ-када мәгариф һәм мәдәни-агарту учреждениеләре, фәнни оешмалар (к. *Гыйльми үзәк*), туган якны һәм татар халкын өйрәнү җәмгыятьләре (к. *Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте, Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросы, Татарстанны гыйльми өйрәнү җымгыяте, Татар мәдәнияте йорты*) эшчәнлегендә көчле үсеш күзәтелә. Совет, партия, мәхкәмә һәм башка хөкүмәт органнары өчен милли кадрлар әзерләү (к. *Төпләндерү*), дәүләти һәм иҗтимагый оешмаларда, мәдәни-агарту учреждениеләрендә татар телен гамәлгә кертү программасын тормышка ашыру (к. *Татар телен гамәлгә кертү комиссиясе*) буенча эш башлана. Вакытлы матбугат, китаплар нәшер итү, әдәбият һәм сәнгать юнәлешендә аеруча зур адымнар ясала.

Шул ук чорда, Коммунистлар партиясенең респ-када бөекдержавачыл шовинизм һәм җирле милләтчелеккә каршы аяусыз көрәш алып барырга чакыруына җавап итеп, татар сәяси җитәкчелеге эчендә татар халкының милли мәнфәгатьләрен суверенлаштыру, татар автономиясенең хокукларын киңәйтү тарафдарлары («уңнар» — М.Х.Солтангалиев, Г.Г.Мансуров, К.Г.Мохтаров, Г.М.Енбаев, Р.Ә.Сабиров һ.б.) һәм хакимият вертикале ныгытылуны актив яклаучылар («суллар» — С.С.Атнагулов, М.С.Сәгыйдуллин һ.б.) арасында идея-сәяси каршылык башлана. Ул Татарстан сәяси җитәкчелегенең Үзәккә тулысынча буйсындырылуы б-н тәмамлана: 1923 нең июнендә РКП(б) ҮК, М.Х.Солтангалиев һәм аның тарафдарларын гаепләү өчен, махсус киңәшмә уздыра (к. *РКП(б) ҮКның дүртенче киңәшмәсе*), 1924–25 тә М.Ю.Борындыков, Г.Г.Мансуров, К.Г.Мохтаров, Р.Ә.Сабиров Мәскәүгә, икенчел дәрәҗәдәге вазифаларга күчерелә. Большевиклар җитәкчелеге максатчан рәвештә барлык иҗтимагый-сәяси оешмаларны үзенә буйсындыру юнәлешендә эш алып бара; коммунистик булмаган сәяси партияләр һәм берлекләр эшчәнлеге тыела.

1930 елларда, СССРның яңа Конституциясе турында фикер алышулар барышында, Татарстан АССРын союздаш респ-ка итеп үзгәртү тәкъдиме кабат күтәрелә. 1936 ның 25 ноябрендә, Советларның 8 нче (чираттан тыш) съездында, совет респ-калары һәм өлкәләре б-н әйләндереп алынганлыктан Башкортстан һәм Татарстан респ-каларының СССР составыннан чыгу мөмкинлеге юклыгын сәбәп итеп, И.В.Сталин тәкъдимне кире кага. Шул рәвешле ТАССРның беренче Конституциясе 1937 дә генә кабул ителә, 1938 дә ТАССР ЮСның беренче составы сайлана (к. *Татарстан Республикасы Югары Советы*), респ-каның иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади һәм мәдәни тормышына кагылышлы иң әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итү вәкаләте аңа тапшырыла. Әмма Сталин җитәкчелеге тарафыннан максатчан рәвештә алып барылган хакимиятне үзәкләштерү сәясәте нәтиҗәсендә әлеге хокуклар коры формальлеккә әверелеп кала. 1937–38 еллардагы «зур террор» Татарстан халыклары тормышындагы иң фаҗигале чорларның берсе була: милли-буржуаз, солтангалиевчел, троцкийчыл, бухаринчыл һ.б. оешмаларда торуда, корткычлыкта һ.б. эшләрдә гаепләгән ялган ялалар тагылып, респ-каның иң күренекле сәясәт эшлеклеләре, фән һәм иҗат интеллигенциясе вәкилләреннән бик күпләр юк ителә (к. *Репрессияләр*).

1920 елларның 2 нче яртысыннан ил җитәкчелегенең милли-мәдәни сәясәтендәге үзгәрешләр рус булмаган халыкларның милли-мәдәни үзенчәлекләрен үстерүгә чикләр куя. Татар алфавитының ике тапкыр алыштырылуы (1927, 1939), 1930–50 елларда татар матбугатының, милли уку йортларының, мәдәният учакларының бер-бер артлы ябылуы, мәктәпләрнең рус телендә генә укытуга күчерелүе, ш.у. җәмгыятьнең кырыс идеологик контрольдә торуы һәм атеистлаштырылуы татар халкының милли мәдәнияте үсешен нык тоткарлый.

*Бөек Ватан сугышы* елларында Татарстан Совет Армиясенең тыл базаларыннан берсенә әверелә. Респ-кага 70 тән артык завод һәм фабрика, СССР ФА оешмаларының бер өлеше (к. *СССР Фәннәр Академиясе оешмаларының Казан төркеме*), СССР Финанс халык комис-ты, Дәүләт банкы һ.б. ведомстволар эвакуацияләнә (ТАССРга барлыгы 226 мең кеше эвакуацияләнә). Респ-ка пр-тиеләрендә 600 дән артык исемдәге корал, сугыш кирәк-яраклары (хәрби продукциядән — Пе-2, Пе-8 бомбардировщиклары), сугышчылар өчен хәрби кием-салым җитештерелә. Татарстан халкы фронтка актив рәвештә ярдәм күрсәтә, ш.и. танк колонналары (*«Татарстан комсомолы»*, *«Татарстан колхозчысы»*, *«Красная Татария»*), авиаэскадрильялар (*«Совет Татарстаны»*) төзү һ.б. өчен акча җыеп тапшыра (сугыш елларында, төрле сугышчан техника төзү өчен, респ-када 380 млн. сум акча җыела). Совет Армиясен тулыландыру өчен, ТАССРдан 560 меңнән артык кеше алына. 100 меңнән артык сугышчы орден һәм медальләр б-н бүләкләнә, 200 дән күбрәк кеше Советлар Союзы Герое исеменә лаек була, 50 кеше — Дан орденының тулы кавалеры. Бүләкләнгәннәр арасында татар милләте вәкилләре яки Татарстанда яшәгән П.М.*Гаврилов*, М.П.*Девятаев*, М.М.*Җәлил*, Г.К.*Заһитов*, А.М.*Матросов* һ.б. бар; 300 меңнән артык кеше фронтта һәлак була.

Сугыш елларында Татарстанның гуманитар галимнәренә карата идеологик басым көчәя: 1944 елның 9 августында ВКП(б) ҮКның *«Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»* карары кабул ителә, анда бер төркем тарихчы һәм язучыларның Татарстан тарихын як-

тыртканда милләтчелек рухында җитди ялгышлар җибәргәнлегә әйтелә (Алтын Урда чорын күпертеп күрсәтү, Идегәйгә багышланган ханнар-феодаллар дастанын популярлаштыру һ.б.). Татарларның этник тарихын аларның килеп чыгышын болгарлардан исәпләүче концепция кысаларында гына өйрәнелергә тиеш дип карала (к. *СССР Фәннәр Академиясе фәнни сессиясе*). Татар халкы тарихын ясалма рәвештә Алтын Урда тарихыннан аеру милли тарих һәм мәдәният өлкәсендәге тикшеренүләргә җитди зыян китерә, респ-каның язучылары, композиторлары, сынлы сәнгать осталары иҗатына тискәре йогынты ясый.

«Хрущёв җепшеклеге» елларында респ-ка халыкларының мәдәниятен үстерү һәм традицияләрен тергезү юнәлешендә уңышлы адымнар ясала башлый (к. *Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы*). Шушы чорда 1920–50 елларда ялган яла б-н гаепләнгән бик күпләрне рәсми рәвештә аклау башлана (к. *Репрессияләнүчеләрне аклау*).

1980 елларга Татарстан а.х., сәнәгать, фән һәм мәдәният өлкәләрендә заманча үсешкә ирешкән төбәккә әверелә. 1980 елларның 2 нче яртысында илдә яңа социаль-икътисади һәм сәяси курс («үзгәртеп кору») тормышка ашырыла башлау б-н бәйле рәвештә, Татарстан халыкларының иҗтимагый тормышында зур үзгәрешләр була. Хәбәрдарлык һәм күппартиялелек шартларында формаль булмаган һәм милли-демократик хәрәкәтләрнең активлыгы көчәя; респ-када төрле милли иҗтимагый-сәяси оешмалар төзелә (*Бөтентатар иҗтимагый үзәге, Болгар милли конгрессы, Татар милли бәйсезлек партиясе «Иттифакъ»* һ.б.); респ-каның сәяси статусын һәм суверенитетын киңәйтү өчен көрәш башлана, һәм ул 1990 ның 30 августында ТАССР ЮС тарафыннан *Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация* кабул ителү б-н тәмамлана. 1992 нең 21 мартында үткәрелгән респ-ка референдумында ТРның дәүләт статусы билгеләнә. 1995 тә ТР Дәүләт Советына сайлаулар уздырыла. РФ һәм ТР хөкүмәтләре тарафыннан 1994 нең 15 февралендә кул куелган «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Шартнамә федераль үзәк һәм респ-ка арасында үзара икътисади һәм этномәдәни мөнәсәбәтләрнең тотрыклылануына китерә. Бу елларда фәнни һәм иҗтимагый-сәяси тормыш активлаша. 1992 дә *Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе* оештырыла. Казанда 1991 дә — Тюркологларның алтынчы конференциясе, 1992 дә — 1 нче Бөтендөнья татарлары конгрессы (к. *Бөтендөнья татарлары конгресслары*), 1997 дә һәм 2007 дә Татарстан халыклары съездлары уздырыла. Респ-ка башкаласы татарларның төрле төбәкләрдәге милли-мәдәни автономияләре (к. *Татарстанның милли-мәдәни автономиясе*) үзәгенә әверелә.

1999 ның 1 сентябрендә РФ Президенты В.В.Путин һәм ТР Президенты М.Ш.Шәймиев «Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итү турында»гы Фәрманга кул куя. Бәйрәмгә әзерләнү барышында шәһәрнең тарихи үзәк өлеше реконструкцияләнә, дистәләгән зур җәмәгать биналары, шәһәр инфраструктурасы объектлары реставрацияләнә, ш.и. метроның беренче чираты төзелә, халыкка транспорт һәм социаль хезмәт күрсәтү яхшыра. 2000 нең ноябрендә Казан Кремле ЮНЕСКО бөтендөнья мирас ядкәрләре исемлегенә кертелә. 2005 нең 30 августында Казан шәһәренә нигез салынуга 1000 ел тулуны бәйрәм итү РФ һәм ТР тарихына зур халыкара вакыйга булып кереп кала, халыкара масштаблы вакыйгага әверелә, киң халыкара яңгыраш ала. Юбилей тантаналары кысасында Казанда БДБ илләре дәүләт башлыклары Советы саммиты (26–27 август) уздырыла. РФнең 81 субъекты башлыклары, федераль министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре катнашында РФ Дәүләт Советы утырышы уза. Шәһәр РФнең төрле төбәкләреннән, якын һәм ерак чит илләрдән 20 меңнән артык рәсми затлар һәм кунаклар кабул итә. Казанлылар һәм башкала кунаклары өчен дистәләгән массакүләм мәдәният, спорт һ.б.ш. бәйрәм чаралары оештырыла. Тантана барышын федераль басмалар, телевидение һәм радио каналлары һәм агентлыклары, ш.у. АКШ, Бөекбритания, ГДР, Франция, Чехия, Дания, Польша, Төркия, Япония һ.б. илләр массакүләм мәгълүмат чараларының 1100 дән артык журналисты яктырта.

*Әд.:* Таһиров И.Р. Без тарихта эзлебез. К., 2016; Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Фёдоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973; Фахрутдинов Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984; Исхаки Г. Идель-Урал: Политическая история татар. К., 1991; Алишев С.Х. Тернистый путь борьбы за свободу: Социально-освободительная борьба татарского народа. 2-я половина XVI–XIX вв. К., 1999; Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX в.). К., 1999; шул ук. История национальной государственности татарского народа и Татарстана. К., 2000; История татар с древнейших времён. К., 2002–14. Т. 1–7; Татарстан: вехи истории. 1920–2014. К., 2010.

## IV. СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДИ ҮСЕШ

Татарстан Республикасы иң мөһим транспорт магистральләре киселешендә урнашкан, бай табигый ресурсларга, диверсификацияләнгән көчле җитештерү базасына, нык үскән инфраструктурага, югары интеллектуаль мөмкинлекләргә, квалификацияле эшче көчләргә ия. РФнең икътисади яктан иң нык үскән субъектлары исәбенә керә. 2013 елда респ-ка икътисадында 1,82 млн. кеше хезмәт куя, тулай төбәк продукты (ТТП) күләме 1520 млрд. сум тәшкил итә (РФдә 5 нче күрсәткеч), шуның өчтән бере Казанда җитештерелә. Икътисадның сальдодагы финанс күрсәткече (табыш минус зыян) 219,5 млрд. сум була. 2012 дә ТТП структурасында сәнәгать өлеше — 42,1%, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү секторы — 14,5%, төзелеш — 10% тан артык, а.х. — 7,9%, транспорт өлеше 5,8% тәшкил итә.

1990 еллар ахырыннан башлап, респ-каның ТТП бәясе тәңгәлләштерелгән бәяләрдә — 3 тапкыр арта. 2005–14 тә, җан башына исәпләгәндә, ТТП күләме якынча 3,5 чамасы арта һәм 434,5 мең сумга җитә.

Татарстанда төп капиталга инвестицияләр салу элеккечә үк тотрыклы үсеш кичерә. Аларның күләме буенча респ-ка — Идел буе федераль округ төбәкләре арасында 1 нче, РФ төбәкләре арасында 6 нчы урынны били. 2005 ел б-н чагыштырганда, 2015 кә төп капиталга 3 тапкырдан артыграк инвестицияләр салына. 2015 тә төп капиталга 617,2 млрд. сум инвестиция салына, 320 млрд. сумнан артыклык төп фондлар гамәлгә кертелә. 2015 башына икътисадка кертелгән кредитлар 800 млрд. сум, ә бюджет чыгымнары 248,9 млрд. сум тәшкил итә.

Инновацион һәм инвестицион эшчәнлекне активлаштыру өчен уңайлы шартлар булдыруга юнәлтелгән чаралар комплексы гамәлгә ашырыла. Респ-кадагы инновацион-актив пр-тиеләрнең өлеше Россиядәге уртача күрсәткечтән югарырак (20,5%), ул илдә 4 нче урынны били. Республиканың ТТПнда инновацион товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең чагыштырмача өлеше 20,4% тәшкил итә, бу күрсәткеч гомумроссия уртача күрсәткеченнән 2,5 тапкыр югарырак. ТРда РФдә чыгарылган нефтьнең 6% тан артыграк өлеше табыла, йөк автомобильләренең 30% тан артыгы, автомобильләр һәм а.х. машиналары өчен шиннарның һәм ясалма каучукның 33% тан артыгы, синтетик сумалаларның һәм пластмассаның 43% ы, полиэтилен һәм стиролның 50% чамасы җитештерелә. Авыл хуҗалыгы продукциясенең гомуми күләме буенча респ-ка РФ субъектлары арасында 3 нче урынны тота. Россиядәге а.х. җирләренең 2,3% ын биләүче ТР илнең а.х. продукциясенең 4,2% ын җитештерә.

Респ-ка социаль хәле чагыштырмача уңай төбәкләр төркеменә керә. 2005–15 тә җан башына исәпләнгән уртача керемнәр 4 тапкыр (31,4 мең сумга кадәр) арта. Шуның б-н бергә җан башына уртача акчалата керем б-н яшәү минимумы нисбәте (сатып алу сәләте) 3 тапкырдан 4,2 тапкырга җитә. Шушы чор эчендә респ-када уртача номиналь хезмәт хакы 4 тапкыр арта һәм 29 мең сумга җитә, айлык пенсиянең уртача күләме 4,8 тапкыр арта һәм 11,6 мең сум тәшкил итә. 2005–15 тә акчалата керемнәре яшәү минимумыннан түбәнрәк булганнарның өлеше 12,8% тан 7,6% ка кала.

Кулланучылар базары динамикалы үсеш кичерә: 2005–15 тә ваклап сату сәүдәсе әйләнеше күләме тәңгәлләштерелгән бәяләрдә — 4,8 тапкыр, җәмәгать туклануы күләме — 3,2 тапкыр, халыкка түләүле хезмәт күрсәтүләр күләме 4,6 тапкыр арта.

Респ-када инфраструктураны үстерүгә зур игътибар бирелә. 2005–15 тә гомуми кулланудагы каты түшәмәле автомобиль юлларының тыгызлыгы 1000 *км*² терр-ягә 272 *км* дан 423 *км* га, халыкның шәхси җиңел машиналары саны 1000 кешегә 134,3 тән 275 берәмлеккә җитә; гомуми куллану челтәрендә фатир телефон аппаратлары 1000 кешегә шәһәр җирендә 233,2 данәгә кадәр, авылларда

*2 нче таблица*

2013 елда Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының һәм Идел буе федераль округы кайбер төбәкләренең социаль-икътисади хәленең чагыштырма күрсәткечләре

| Административ территориаль берәмлек | Җан башына төбәк тулай продукты, сум (2012 ел) | Икътисадта эшләүчеләргә исәпләнгән номиналь уртача хезмәт хакы, сум | Халыкның торак б-н тәэмин ителеше, 1 кешегә гомуми мәйдан, $м^2$ | Төп капиталга инвестицияләр, млрд. сум | Каты түшәмәле гомуми файдаланудагы автомобиль юллары, 1 мең $км^2$ территориягә туры килгән юллар, *км* | Шәһәр/авыл халкының гомуми файдалану челтәрендәге телефон аппаратлары б-н тәэмин ителеше, 1 мең кешегә, данә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Россия Федерациясе | 348599 | 29792,0 | 23,4 | 13255,5 | 54 | 237,7/108,3 |
| Татарстан Республикасы | 376889 | 26034,5 | 24,2 | 520,2 | 405,9 | 233,2/165,2 |
| Башкортстан Республикасы | 284068 | 22377,4 | 23,1 | 266,2 | 206,5 | 205,4/178,1 |
| Удмурт Республикасы | 244746 | 21053,4 | 20,9 | 71,8 | 237,6 | 210,8/96,2 |
| Чуаш Республикасы | 174294 | 19387,5 | 24,8 | 59,1 | 404,3 | 181,5/74,9 |
| Түбән Новгород өлкәсе | 254631 | 23572,9 | 25,1 | 272,2 | 287,9 | 295,5/126,3 |
| Самара өлкәсе | 293001 | 23469,5 | 23,4 | 262,3 | 283,7 | 230,4/101,6 |

123,9 дан 266 данәгә кадәр арта. Телекоммуникация челтәрләре тулысынча цифрлы инфраструктурага күчерелә. 1 кешегә исәпләнгән гомуми торак мәйданы 21,9 дан 25,2 $м^2$ га җитә.

Җитештерү һәм финанс-инвестиция эшчәнлеге, ш.у. социаль өлкә күрсәткечләре катнашкан гомуми рейтинг буенча Татарстан Идел буе федераль округы төбәкләре арасында 1 нче урынны били (2 нче табл. кара).

**Сәнәгать.** Төбәктә беренче сәнәгать пр-тиеләре — казна һәм хосусый *мануфактуралар* — 17 йөз ахырында — 18 йөз башында оештырыла башлый. Бу чорда *Казан постау мануфактурасы* (1714 тә нигезләнә), *Казан адмиралтействосы* (1718), *Помпа каеш-күннәре заводы* (1719), *Күн эшләнмәләр мануфактуралары, бакыр кою заводлары,* тукыма, аркан-эрләү, язу кәгазе һәм *комач мануфактуралары, сабын җитештерү* шактый зур роль уйный. 19 йөздә, бигрәк тә 1860–70 еллар буржуаз реформаларыннан соң, Казан губернасының күп кенә җитештерү тармакларында механикалаштырылган заводлар һәм фабрикалар барлыкка килә: химия сәнәгатендә — *Шәм-стеарин, сабын кайнату, глицерин җитештерү химия заводы, Казан дары заводы,* «П.К.Ушков һәм К° химия заводлары ширкәте» з-длары, җиңел сәнәгатьтә — *Алафузовларның завод-фабрикалар һәм җитештерү сәүдә-сәнәгать ширкәтенә* караган җитен туку һәм күн пр-тиеләре, Ә.Я.Сәйдәшев һәм Б.М.Субаевның — мех, француз эшмәкәре Л.Зальмның — күн, А.О.Тихомирнов, И.В.Чернышёвның — постау, бертуган Комаровларның киез аяк киемнәре ф-калары һ.б., азык-төлек продуктлары җитештерүдә — Стахеевларның пар тегермәннәре, Д.М.Вараксинның — аракы-шәраб, В.Г.Стахеев, И.В.Александровның — шәраб, О.Э.Петцольд, И.В.Александровның сыра з-длары һ.б. Металл эшкәртү («Кавказ һәм Меркурий» җәмгыятенең суднолар ремонтлау һәм суднолар төзү з-ды, Паратск судно ремонтлау остаханәләре, А.А.Свешниковның, М.Я.Рамның механика з-длары һ.б.), агач эшкәртү (Америка эшмәкәре Э.Ропсның агач эшкәртү з-ды, такта яру, паркет һәм шырпы ф-калары), төзелеш материаллары сәнәгате (пыяла һәм *кирпеч җитештерү*) билгеле бер дәрәҗәдә үсеш ала. Сәнәгать пр-тиеләренең күпчелек өлеше Казанда туплана, Чистай, Мамадыш шәһәрләрендә, Мамадыш өязенең Кукмара авылында, Казан өязенең Паратск бистәсендә аерым пр-тиеләр була. 20 йөз башында Россия губерналары арасында Казан губернасы химик матдәләр эшләп чыгару буенча — 1 нче, сабын җитештерүдә — 4 нче, күн җитештерүдә 6 нчы урынны били. Эре сәнәгать б-н бер үк вакытта вак һөнәрчелек секторы: *урман-агач эшкәртү кәсепчелеге, мичкә-кисмәк кәсепчелеге, экипаж-лар ясау кәсепчелеге, селте-поташ кәсепчелеге, күн эшләү һөнәрчелеге, тимерчелек кәсебе, каюлы күн кәсепчелеге* дә үсеш кичерә; алар барысы да диярлек Казан, Лаеш, Мамадыш, Козьмодемьянск, Чабаксар, Цивильск, Ядрин һәм кайбер башка өязләрдә туплана. Беренче бөтендөнья сугышы елларында фронт ихтыяҗларына эшләүче эре фабрикаларга нигез салына: хәрби киемнәр өчен — «Победа», хәрби аяк киемнәре өчен — «Поляр» (хәзерге «*Спартак*»); Казан губ-насына эре суднолар төзү һәм металл эшкәртү пр-тиеләре (к. *«Серго исемендәге завод», Яшел Үзән А.М.Горький исем. заводы*) эвакуацияләнә. Окт. рев-циясеннән соң сәнәгатьне национализацияләү үткәрелә. 1914–21 дә хәрби продукция чыгару б-н бәйләнмәгән күпчелек пр-тиеләр ябыла, сәнәгать продукциясе җитештерү 4 тапкырдан күбрәккә кими. Яңа икътисади сәясәт (нэп) елларында завод һәм фабрикалар хуҗалык исәбендәге трестларга берләштерелә («Кожтрест», «Электротрест», «Металлотрест», «Лесотрест», «Пищетрест», «Силикаттрест», «Татваленок», «Татодежда», «Текстильтрест»), 7 кантон берләшмәсе төзелә (Буа, Бөгелмә, Алабуга, Мамадыш, Спас, Чаллы, Чистай), кайбер пр-тиеләр дәүләт учреждениеләренә, кооперативларга һәм шәхси затларга арендага бирелә, нәтиҗәдә, 1927 гә җитештерү күләме 1913 ел дәрәҗәсен узып китә. 1929–41 еллардагы индустрияләштерү барышында илдә иң зур мех, киез итек һәм киез, фанера комб-тлары, авиакомб-т, оптик механика з-ды, ясалма каучук, кинофототасма пр-тиеләре, илдә беренче кетгут, ясалма күн з-длары һ.б. төзелә, ит, сөт, икмәк пешерү һәм кондитер сәнәгатьләре индустриаль нигезгә күчерелә, электр энергетикасына нигез салына, гамәлдәге фабрика һәм заводларның күпчелеге үзгәртеп корыла. Нәтиҗәдә, 1940 елга сәнәгать продукциясе чыгару 12 тапкыр арта һәм респ-каның тулай продукциясендә 86% ны алып тора.

Бөек Ватан сугышы башлану б-н, Татарстанга 70 тән артык завод һәм фабрика (шуларның 30 ы эре), ш.и. Мәскәүнең С.П.Горбунов исем. авиация з-ды, 16 нчы Воронеж моторлар төзү з-ды, Мәскәүнең 2 нче сәгать з-ды, Киев теш бурлары з-ды эвакуацияләнә. Респ-ка илнең зур тыл базасына әверелә. Татарстан пр-тиеләре 600 дән артык исемдә сугыш кирәк-яраклары, хәрби кием-салым эшләп чыгара. 1941–45 тә тулаем сәнәгать продукциясе күләме 2,2 тапкыр, ш.и. машиналар төзелеше продукциясе 6,8 тапкыр арта.

Респ-каның сәнәгать җитештерүе тарихында яңа, гаять мөһим этап 1940–50 елларда Ромашкино, Баулы, Зәй һ.б. зур нефть ятмаларын сәнәгый үзләштерү б-н бәйле. 1950–70 елларда нефть чыгару күләме кызу темплар б-н арта һәм 1975 кә иң зур күрсәткечкә — елына 104,6 млн. *т* га җитә. 1970 елларда ТАССР илдә чыгарылган нефтьнең 30% чамасын бирә. Нефть һәм иярчен газ чыгару күләмнәре арту б-н бер үк вакытта аларны эшкәртү пр-тиеләре — *Миңлебай газ эшкәртү заводы*, «*Казан органик синтез*» з-ды,



Зәй ГРЭСы.



Түбән Кама ГЭСы.

*«Түбәнкаманефтехим»*, *«Түбәнкамашин»* ҖБләре төзелә. *Нефть-газ чыгару сәнәгате, нефть-газ эшкәртү сәнәгате, нефть химиясе сәнәгатенең* ихтыяҗлары *нефть-газ машиналары төзү сәнәгатен* тудыруга һәм шуның б-н төзелеш материаллары сәнәгате куәтләрен арттыруга, *Урыссу ГРЭСын* (1944), *Зәй ГРЭСын* (1962), *Түбән Кама ГЭСын* (1979), Казан, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә ТЭЦлар төзүгә этәргеч бирә. Машиналар төзү һәм металл эшкәртү кызу темплар б-н үсә башлый: *«Казанкомпрессормаш»*, *«Вакуумаш»*, «Әлмәт насослар заводы» ҖБләре төзелә; *авиация сәнәгате* составына *Казан вертолёт заводы* керә. Приборлар төзү, аерым алганда, радиоэлектрон (*«Радиоприбор»*, *«Свияга»*, *«Электроприбор»*, *«Элекон заводы»* һ.б. пр-тиеләр) һәм электрон-хисаплау (*Казан хисаплау системалары җитештерү берләшмәсе*) приборларын төзү көчле үсеш ала. Чаллы шәһәрендә йөк автомобильләре чыгару заводларының эре комплексы төзелү б-н (беренче чираты 1969–75 тә сафка баса), Татарстанда автомобиль сәнәгатенә нигез салына. Респ-каның сәнәгать комплексында җиңел сәнәгатькә караган аяк киемнәре, мех, күн җитештерүче зур берләшмәләр; киез итек һәм киез, җитен туку комб-лары, тегү һәм трикотаж ф-калары лаеклы урын алып тора. Яшел Үзәндә фанера җитештерүче зур пр-тиеләр уңышлы эшли. Азык-төлек сәнәгатендә ит, сөт-сыр һәм шикәр тармаклары мөһим роль уйный.

Казан–Яшел Үзән сәнәгать төйнәлеше тагын да үстерелә, яңалары — *Әлмәт–Бөгелмә сәнәгать төйнәлеше* һәм *Түбән Кама территориаль-җитештерү комплексы* формалаша. 1940–85 тә сәнәгать продукциясенең гомуми күләме 72 тапкыр арта, ш.и. тармаклар буенча: машиналар төзү һәм металл эшкәртү — 1190,1 тапкыр, электр энергетикасы — 159,1, ягулык — 106,3 (1950–80), химия һәм нефть химиясе — 82,5, төзелеш материаллары сәнәгате — 79,9, азык-төлек — 7,5, урман һәм агач эшкәртү — 3,8, җиңел сәнәгать 5,7 тапкыр артыграк продукция эшләп чыгара. Сәнәгать тармакларында эшләүчеләр саны 610,2 мең кешегә җитә. ТАССР илнең иң көчле индустриаль үсеш алган, беренче чиратта илкүләм әһәмиятле җитештерү средстволары (җиһазлар, чимал, материаллар), ш.у. оборона максатындагы продукция чыгаручы төбәкләренең берсенә әверелә.

1980 еллар ахырыннан ил кискен сәяси һәм икътисади кризис юлына керә, нәтиҗәдә, 1990 еллар уртасына респ-каның сәнәгать җитештерүе күләме 40% ка кими, сәнәгатьтә эшләүче белгечләр саны кыскартыла, күп кенә пр-тиеләр банкротлыкка чыга һәм ябыла. Машина төзелеше, металл эшкәртү (бигрәк тә оборона сәнәгате комплексы), җиңел сәнәгать иң дәвамлы һәм иң тирән кризис кичерә. 1990 елларның масштаблы институциональ үзгәрешләре һәм хосусыйлаштыру барышында хосусый, катнаш (хосусый-дәүләт),



**ТР предприятиеләре продукциясе:** 1. «FIAT Ducato» микроавтобусы («SOLLERS» ҖЧҖ, Алабуга ш.); 2. «КАМАЗ-Т-215» тракторы («КамАЗ» АҖ, Чаллы ш.); 3. Автомобильләр өчен «KAMA EURO 129» һәм «KAMA EURO 131» шиннары («Түбәнкамашин» АҖ); 4. Спиральле-җөйле торбалар (Әлмәт торба заводы); 5. «Ключище керамикасы» заводы (Югары Ослан районы); 6. Электр тоташтыргычлары («Элекон заводы» АҖ, Казан); 7. Мех эшләнмәләр («Мелита» АҖ, Казан); 8. Аяк киемнәре модельләре («Спартак» АҖ, Казан); 9. Юу чаралары («Нәфис Косметикс» АҖ, Казан).




**ТР предприятиеләре продукциясе:** 1. Якын араларга очучы Ту-334 пассажир самолёты; 2. Уртача ераклыкка очучы Ту-214 пассажир самолёты; 3. Ракета йөртүче Ту-160 стратегик бомбардировщигы (барысы да – Казан авиация җитештерү берләшмәсе); 4. АИ-22 авиация турбореактив двигателе; 5. НК-93 авиация турбовентилятор двигателе (икесе дә – Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе); 6. Күпмаксатлы «АНСАТ» җиңел вертолёты; 7. Урта класслы күпмаксатлы Ми-38 вертолёты (икесе дә – Казан вертолёт заводы); 8. «Татарстан» сак корабле (Яшел Үзән А.М.Горький исем. заводы); 9. «КАМАЗ–6540» үзбушаткычы; 10. «КАМАЗ–6460» тягачы; 11. «КАМАЗ–5299» шассие җирлегендәге автобус (барысы да – «КАМАЗ» АҖ).

уртак, чит ил һәм кече пр-тиеләр барлыкка килә. Бу чорда респ-ка җитәкчелеге сәнәгатьне дәүләттән аеру темпларын акрынайту тактикасын (базарга «йомшак» керү сәясәтен) алып бара, шул рәвешле Россиянең башка төбәкләре б-н чагыштырганда икътисади реформаларның тискәре нәтиҗәләрен киметү мөмкин була. 1990 елларның 2 нче яртысыннан ТР хөкүмәте сәнәгать тармакларын үстерүнең комплекслы программасын эшли, респ-ка пр-тиеләрендә эчке структураны һәм идарә системасын оптимальләштерү, халыкара сыйфат стандартларын кертү процесслары башлана; респ-ка эчендә кооперация тирәнәйтелә. 1995 тән башлап, сәнәгатьнең экспортка продукция чыгаруга йөз тоткан тармакларында, ш.у. нефть-газ чыгару җиһазлары, җиңел машиналар, азык-төлек продуктлары җитештерү тармакларында үсеш күзәтелә башлый; 1998 дән күпчелек тармаклар тотрыклы үсеш фазасына керә.

2000 елларда ТРның сәнәгать сәясәте пр-тиеләргә 1990 елларның кризис шартларында ярдәм итүдән аларның инновацион үсешенә этәргеч бирүгә күчә, моның төп максаты — җитештерүнең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм югары өстәмә бәягә ия булган, көндәш-

*3 нче таблица*

1940–2013 елларда ТРда сәнәгать продукциясенең төп төрләрен җитештерү

| | 1940 | 1950 | 1960 | 1970 | 1980 | 1990 | 1995 | 2000 | 2013 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Нефть, млн. *т* | – | 0,9 | 46,3 | 101,9 | 83,1 | 35 | 26 | 27,2 | 32,8 |
| Иярчен газ , млн. *м*³ | – | – | 1432 | 3882 | 3250 | 1269 | 848 | 757 | 946 |
| Ябыштырылган фанера, мең *м*³ | 43,3 | 44,7 | 80,0 | 95,1 | 61,6 | 72,4 | 63,8 | 74,7 | 75,9 |
| Синтетик сумалалар һәм пластик массалар, мең *т* | – | – | – | – | – | 345,4 | 292,7 | 375 | 1560,6 |
| Полиэтилен, мең *т* | – | – | – | – | – | 335,5 | 290,4 | 369,1 | 894,3 |
| Полистирол һәм стирол сополимерлары, мең *т* | – | – | – | – | – | – | – | – | 294,5 |
| Полипропилен, мең *т* | – | – | – | – | – | – | – | – | 209,1 |
| Ясалма каучук, мең *т* | – | – | – | – | – | 434,6 | 174,7 | 219,4 | 646,1 |
| Синтетик юу чаралары, мең *т* | – | – | 6,6 | 46,0 | 48,2 | 48,7 | 19,5 | 30,7 | 167,9 |
| Автомобиль һәм авыл хуҗалыгы техникасы өчен шиннар, млн. данә | – | – | – | – | 6,948 | 12,295 | 7,914 | 8,638 | 12,5 |
| Көнкүреш суыткычлары һәм туңдыргычлары, мең данә | – | – | 3,7 | 179,4 | 350,3 | 413,8 | 372,82 | 111,5 | 278,5 |
| Йөк автомобильләре, данә | – | – | – | – | 45500 | 75983 | 20675 | 23494 | 62377 |
| Җиңел автомобильләр, данә | – | – | – | – | – | 1962 | 8639 | 33671 | 20407 |
| Тракторлар, данә | – | – | – | – | – | – | – | – | 3300 |
| Электр энергиясе җитештерү, млн. *кВт·сәг.* | 331 | 864 | 3321 | 14561 | 32749 | 36543 | 22761 | 23425 | 23226 |

леккә сәләтле продукция эшләп чыгару була. Эре пр-тиеләрне, комплектлау эшләнмәләре һәм иярчен продукция чыгаручы вак һәм урта пр-тиеләрне, фәнни-техник, финанс-кредит учреждениеләрен, уку йортларын һ.б.ны берләштерүче тармакара һәм төбәкара кластерлар формалаша. Югары технол. продукция җитештерүгә кече һәм урта бизнесны җәлеп итү максатында респ-када *технопарклар* һәм сәнәгать округлары челтәре булдырыла (Казанда «Идея», «Химград», Чаллы шәһәрендә «Мастер», Түбән Кама сәнәгать округы һәм Түбән Кама р-нында «Кама Аланы» индустриаль паркы һ.б.), интенсив рәвештә «Иннополис» махсус икътисади зонасы формалаша. Сәнәгатькә капитал салулар даими рәвештә үсә. Респ-ка икътисады өчен әһәмиятле һәм иң эре инвестиция проектларын: Түбән Кама шәһәрендә «ТАНЕКО» АҖнең югары технологияле заманча нефть эшкәртү һәм нефть химиясе з-длары комплексын төзү, нефть химиясе продуктларының өр-яңа һәм сирәк төрләрен чыгаруны оештыру өчен «Казаньоргсинтез» һәм «Түбәнкаманефтехим» АҖләрендә җитештерүне модернизацияләү, Чаллы шәһәрендә халыкара стандартларга туры килгән автомобиль узелларын һәм җиңел автомобильләрнең яңа маркаларын җитештерүне оештыру, Менделеев шәһәрендә «Аммоний» АҖнең аммиак, метанол, карбамид җитештерү комплексын төзү тәшкил итә. «Алабуга» махсус икътисади зонасында чит ил инвесторлары катнашында автомобиль, нефть химиясе пр-тиеләре, заводлары һ.б. эшли һәм төзелә.

2014 кә ТР икътисадында сәнәгать өлешенә төп фондларның 45,9% ы (1170,5 млрд. сум), барлык эшләүчеләрнең 22,1% ы (349,7 мең кеше тирәсе), инвестицияләрнең 58,6% ы (215,6 млрд. сум), товар экспортының 100% чамасы (18,3 млрд. АКШ доллары), табышның 77,2% ы (164,6 млрд. сум), тулаем төбәк продуктының 42% ы (639,1 млрд. сум) туры килә. Респ-када 8600 эре, урта һәм кече сәнәгать пр-тиесе эшли. 2015 тә аларда барлыгы 1,8 трлн. сумлык товар җитештереп сатылган һәм хезмәт күрсәтелгән; шуларның 70%ы — эшкәртү тармакларына, 23,6%ы — файдалы казылмалар чыгаруга, 6,4% ы электр энергиясе, газ һәм су җитештерү һәм сатуга туры килә. Җитештерүнең гомуми күләмендә иң зур урынны *«Татнефть»*, *«ТАИФ»*, *«КАМАЗ»* компанияләр төркеме, «Казан вертолёт заводы», «Генерирующая компания», «Сетевая компания», «Яшел Үзән суднолар төзү заводы», *«Нәфис Косметикс»* акц. җәмгыятьләре, «Форд Соллерс Холдинг» («SOLLERS») ЖЧҖ, «Просто молоко» идарәче компаниясе алып тора. Машиналар төзү, нефть химиясе, нефть эшкәртү иң зур үсешкә ия.

ТР пр-тиеләре продукциясенең РФ җитештергән продукция күләмендәге өлеше (% ларда): газ турбиналары — 95, стирол — 60, авыр классның йөк автомобильләре — 55 (барлык йөк автомобильләренең 30 дан артыгы), нефть чыгару өчен үзәктән кугыч насослар — 50 дән артык, термопласт торбалар һәм үткәргеч торба детальләре — 50 тирәсе, ясалма каучук — 45, автомобиль шиннары — 24,4 тән артык, тракторлар — 24 тирәсе, көнкүреш суыткычлары һәм туңдыргычлары — 9 дан артык, синтетик юу чаралары — 12, нефть — 6,4 (1940–2013 тә Татарстанда сәнәгать продукциясенең төп төрләрен җитештерү күрсәткечләре 3 нче таблицада китерелә).

**Төзелеш.** ТРда РФнең иң зур төзелеш комплексларыннан берсе формалаша; респ-каның тулаем төбәк продуктында аның өлешенә 9,5% туры килә. 2014 кә бу тармакта төп фондлары 31,8 млрд. сум булган 6536 төзелеш оешмасы исәпләнә (респ-ка икътисадындагы төп фондлар бәясенең 2,1%ы), эшләүчеләр саны — 105,6 мең кеше (Татарстан икътисадында эшләүчеләрнең 9,9% ы).

Респ-када төзелеш комплексының аякка басуы ил үсешенең төп этаплары булган индустрияләштерү (1930 еллар), халык хуҗалыгын Бөек Ватан сугышыннан соң яңадан торгызу һәм икътисадның шуннан соңгы модернизациясе б-н бәйле. 1950–80 елларда сәнәгатьнең машиналар төзелеше һәм металл эшкәртү, нефть чыгару һәм нефть химиясе тармакларының алга китүе, *сәнәгать төзелешенең*, торак һәм җәмәгать биналары төзелешенең, Әлмәт-Бөгелмә сәнәгать төйнәлешендә һәм Түбән Кама терр.-җитештерү комплексында шәһәрләрнең кызу темплар б-н үсүе аеруча әһәмиятле роль уйный. Совет чоры бишьеллык планнарын гамәлгә ашыру елларында (1929–85) завод һәм фабрикаларны киңәйтү һәм техник үзгәртеп кору бара, 232 зур сәнәгать пр-тиесе төзелә һәм файдалануга тапшырыла, нефть һәм продукт үткәргечләре (к. *«Дуслык»*, *«Төньяк-Көнбатыш магистраль нефть үткәргечләр»*), газ үткәргечләр һәм аларның тармаклары (к. *Газлаштыру*) салына. Күпсанлы а.х. корылмалары, элеваторлар, ашлык саклау урыннары, тегермәннәр, катнаш азык пр-тиеләре һ.б. төзелә, мәдәният-көнкүреш объектлары сафка кертелә. Гомуми мәйданы 90 млн. *м*² булган торак йортлар файдалануга кертелә. Сугышка кадәрге бишьеллыклар чорында (1929–1941 нең беренче яртысы) төзелешкә 593 млн. сумлык (тиңдәш бәяләрдә) капитал салына. 70 кә якын эре һәм 300 дән артык урта һәм кече пр-тие сафка бастырыла (Казанда ТЭЦ-1 һәм ТЭЦ-2, *Казан ясалма күн заводы, Казан ясалма каучук заводы, Казан оптика-механика заводы, Казан авиация җитештерү берләшмәсе һ.б.*).

Бөек Ватан сугышы елларында өстенлек хәрби сәнәгать комплексының яңа куәтләрен төзүгә бирелә. Бу чорда 250 млн. сумлык капитал салына. 22 пр-тие: резина-техник эшләнмәләр з-ды, нефть-май з-ды, механика һәм подшипниклар ремонтлау з-ды (барысы да Казанда), электр станциясе (Алабуга ш.) һ.б. төзелә.

Сугыштан соңгы халык хуҗалыгын торгызу чорында яңа төзелеш җәелеп китә. 1940 еллар ахырында нефть чыгарыла башлау б-н респ-када нефть промыселы корылмаларын яңартып төзү башлана (Миңлебай газ эшкәртү з-ды һ.б.). Казан органик синтез з-ды төзелеше күп катлы биек химик аппаратлар төзү буенча бөтенсоюз индустриаль алымнар мәктәбенә әверелә. Бу чорда энергетика куәтләрен төзүгә (к. *Зәй ГРЭСы, Казан җылылык электр үзәкләре*) зур игътибар бирелә. 1950 еллар ахырында төзелештә җыелма тимер-бетон конструкцияләр һәм детальләр кулланыла башлый. Аларны заводларда күпләп эшләп чыгару төзелеш хезмәтенә зур үзгәрешләр кертә, аның индустриаль агым ысулына күчүен тәэмин итә. Төзелешне механикалаштыру дәрәҗәсе һәм анда монтажлау эшләренең өлеше күтәрелә. Индустриаль алымнарга күчү конструкцияләрне бердәйләштерү, күбесенчә типларга бүлеп проектлаштыру б-н бергә бара. Торак һәм җәмәгать биналары төзелешендә биналарның рациональрәк конструкцияләре кулланыла баш-

лый, эре панельле йортлар төзү үсеш ала. 4 нче һәм 5 нче бишьеллыкларда (1946–60) төзелешкә капитал салу күләме 4,75 млрд. сумга җитә, 48 эре сәнәгать пр-тиесе (*Казан компрессор машиналары төзү заводы*, *Казан сөт комбинаты*, *Казан хисаплау системалары җитештерү берләшмәсе*, эре панельле йортлар төзү з-длары һ.б.) сафка кертелә, гомуми (файдалы) мәйданы 13720,1 мең $м^2$ булган торак йортлар төзелә. Капиталь төзелеш 7 нче, 8 нче һәм 9 нчы бишьеллыкларда (1961–75) тагын да тизрәк үсеш ала. Төзелешне индустриальләштерү нәтиҗәсендә җыелма, тимер-бетон, корыч конструкцияләр кулланыла башлый, эре блоклы монтажлау алдыннан кайбер җыю эшләре җирдә башкарыла, җыю һәм монтаж эшләре конвейерга салына һ.б. Нефть һәм газ чыгару сәнәгатендә җир өсте корылмаларын блоклап төзү киң җәелдерелә, респ-када беренче тапкыр электр контактлы эретеп ябыштыру, автоматлаштырылган агым линияләрендә торбаларны чистарту һәм изоляцияләү үзләштерелә. Бу елларда төзелешкә 20,123 млрд. сумлык капитал салына, 65 тән артык эре сәнәгать пр-тиесе сафка кертелә (Әлмәт «*Нефтемаш*» машиналар төзү з-ды, Лениногорск, Әлмәт шәһәрләрендә приборлар төзү з-длары, *Казан ликёр-аракы заводы* һ.б.). 1969 да иң зур авыр йөк машиналары з-дларының берсе булган КамАЗ һәм Зәй шәһәрендәге тәгәрмәчләр з-ды төзелеше башланып китә. Төзелеш оешмалары а.х.ның җитештерү базасын ныгытуга зур көч кертәләр (терлекчелек комплекслары, ашлык саклау урыннары һ.б. төзелә). Торак һәм җәмәгать биналары төзүнең зур масштаблы программасы үтәлә: респ-ка буенча гомуми (файдалы) мәйданы 22117,8 мең $м^2$ булган торак йортлар, мәдәният һәм көнкүреш максатындагы күпсанлы биналар төзелә. 10 нчы һәм 11 нче бишьеллыкта (1976–85) капиталь төзелеш күләме буенча иң зур күрсәткечләргә ирешелә. Капитал салу күләме 27,06 млрд. сумга җитә. 37 эре сәнәгать пр-тиесе (Әлмәт насослар з-ды, «Түбәнкамашин», «Түбәнкаманефтехим», Яшел Үзән машина төзү з-ды һ.б.), гомуми (файдалы) мәйданы 17563 мең $м^2$ булган торак йортлар файдалануга тапшырыла. 12 нче бишьеллыкта (1986–90) 16,85 млрд. сумлык капитал, башлыча, эшләп торучы пр-тиеләр төзелешенә салына. Гомуми (файдалы) мәйданы 9519,1 мең $м^2$ булган торак йортлар төзелә.



Яңа эре панельле йортлар. Түбән Кама шәһәре

1990 елларда, илдә икътисади кризис башлану б-н, төзелеш күләме күпкә кыскара, төп капитал салулар 70% ка кими. Төзелештәге төп фондларның тузуы 50% ка җитә. Алар структурасында актив өлеш 2 тапкыр кими, һәм аның үсеше 1950 еллар дәрәҗәсенә төшә. 1990–2001 дә төзелештә төп фондларны яңарту коэффициенты 6,5 тапкыр, яраксызга әйләнү коэффициенты 3,7 тапкыр кыскара. 1990 еллар ахырында, инвестицияләр активлыгы арту б-н, төзелеш техникасының саны шактый арта. Бу елларда респ-када торак йортлар (ш.и. *Тузган торакны бетерү программасы* буенча), мәктәпләр, хастаханәләр, газ, электр һәм су үткәрү челтәрләре, юллар төзү җәелдерелә. Җитештерү өлкәсендә капитал салулар, башлыча, пр-тие һәм оешмаларның үз хисабына гамәлгә ашырыла. 1999–2005 тә, Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек уңае б-н, шәһәрнең тарихи үзәгенә капиталь реконструкция үткәрелә, дистәләгән зур җәмәгать корылмалары, шәһәр инфраструктурасы объектлары (ш.и. метро) реставрацияләнә һәм төзелә.

2000 еллар башыннан торак төзелешендә дәүләт инвестиция программалары өстенлекле юнәлешкә әверелә. РФ субъектларында торак төзелешен стимуллаштыручы, яшь гаиләләрне һәм гражданнарның ташламаларга хокуклы башка категорияләрен торак б-н тәэмин итү буенча, ш.у. коммуналь структураны модернизацияләүне күздә тоткан «Россия гражданнарына — арзанлы һәм уңайлы торак» милли проекты гамәлгә ашырылып килә. Аның кысаларында 2013 тә 6703 гаилә тораклы булуга ирешә, шуларның 1458 е — Бөек Ватан сугышы ветераннары, 877 се — яшь гаиләләр. 2011–15 тә балалар бакчасында балаларны урыннар б-н тәэмин итү буенча «Бәләкәч-Малыш» респ-ка программасы гамәлгә ашырыла. 2012 дә мәктәпләрне капиталь ремонтлау буенча респ-ка программасы кысаларында эш башлана. Респ-ка капиталь төзелеш программасы тормышка ашырыла. 2013 елгы Универсиадага әзерлек барышында «Ак Барс» көрәш сарае, Универсиада авылы, Казан теннис академиясе, стендка ату комплексы, ябулы «Акчарлак», «Буревестник» йөзү бассейннары, «КАИ-Олимп» мәдәният-спорт комплексы, «Триумф», «Ватан» спорт-сәламәтләндерү комплекслары, «Казан-Арена» стадионы һ.б. төзелә. Пр-тиеләрнең төп капиталга инвестицияләре шактый арта (млрд. сумнарда): 1998 дә — 7,9, 2000 дә — 31,9, 2011 дә — 245, 2013 тә — 322,3, ш.и. яңа төзелешләргә — 198,6. Респ-ка күләмендәге нефть химиясе комплексын үстерү, оборона сәнәгате комплексын реформалау һәм үстерү, мәгарифне үстерү һәм авылны 2017 гә кадәр социаль үстерү, газлаштыру һәм су б-н тәэмин итү, туфракның уңдырышлылыгын саклау һәм яңадан тергезү һ.б. буенча респ-ка программалары кабул ителә һәм гамәлгә ашырыла. Инвестиция программаларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә төзелеш Татарстан икътисадының иң инновацион актив тармакларының берсенә әверелә.



«Кояшлы шәһәр» торак комплексы. Казан.

2014 тә милек формасы төрле булган төзелеш пр-тиеләре һәм оешмалары тарафыннан 2529 урынлык мәктәпләр, сменага 853 кеше кабул итүгә исәпләнгән һәм 100 ятак-урынлы сәламәтлек саклау учреждениеләре, 10225 урынлык мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, 8723 урынлык клублар һәм мәдәният йортлары һ.б. төзелеп файдалануга тапшырыла; 28824 фатир төзелә.

Төзелеш тармагының иң зур пр-тиеләре: «*Камгэсэнергострой*», «*Татагропромстрой*», «Камаглавстрой», «Татэлектромонтаж», «Татсантехмонтаж», «Востокмонтажгаз» акц. җәмгыятьләре, «Казангипронииавиапром», «Татагропромпроект», «Татинвестгражданпроект» архит-ра-проектлау оешмалары һ.б.




«Түбәнкаманефтехим» предприятиесе панорамасы. Түбән Кама шәһәре



Казан тимер юл станциясе. Пассажирлар платформасы.



Казан елга порты. Пассажирлар зонасы.



Казан метрополитены. «Җиңү проспекты» станциясенең перрон залы.

Татарстанның төзелеш комплексы индустриаль базасын 500 дән артык төзелеш материаллары сәнәгате пр-тиеләре, ш.и. 100 дән артык тимер-бетон һәм товарлыклы бетон, силикат һәм керамик кирпечләр, төзелеш конструкцияләре, термоизоляция материаллары, агач эшләнмәләр җитештерүче 100 дән артык эре һәм уртача зурлыктагы заводлар хасил итә.

*Әд.:* Анализ и основные направления развития и размещения производительных сил Республики Татарстан. К., 1996; Архитектурно-строительный комплекс Республики Татарстан: История, биографии, свершения, надежды. К., 2005; Перспективы развития инвестиционно-строительного комплекса Республики Татарстан. К., 2008; Строительный комплекс Республики Татарстан. К., 2011.

**Транспорт.** ТРның транспорт комплексы автомобиль, һава транспортларын, *тимер юл транспортын, елга транспортын*, үткәргеч торбалар һәм сәнәгать транспортын, ш.у. юллар хуҗалыгын берләштерә; 3480 хуҗалык субъектын үз эченә ала. 2013 тә Татарстан транспорт системасына кергән юлларның озынлыгы: 41027,1 *км* автомобиль юллары (30338,5 *км* каты түшәмәле юллар), ш.и. 1068,9 *км* федераль, 26937,9 *км* респ-ка һәм муниципаль юллар (автомобиль юлларында 3530 дан артык күпер һәм юлүткәргеч төзелгән); 1057 *км* эчке елга юллары, 876,8 *км* гомуми кулланылыштагы тимер юллар, 5993 *км* магистраль нефтьүткәргечләр, 145,2 *км* трамвай юллары (ике юллап исәпләгәндә), 130,2 *км* троллейбус линияләре (ике линияле итеп исәпләгәндә), 15,2 *км* метро юллары. Респ-ка терр-ясеннән Мәскәү–Түбән Новгород–Казан–Уфа, Казан–Оренбург, Казан–Ульянов, Казан–Пермь федераль трассалары; респ-каның 19 районы терр-ясеннән: төньякта — Түбән Вязовой, Яшел Үзән, Казан, Кукмара һәм Әгерҗе аша (Мәскәү–Екатеринбург тимер юл магистрале участогы), көньякта — Нурлат, Бөгелмә һәм Урыссу аша (Мәскәү–Чиләбе тимер юл магистрале участогы) федераль тимер юл магистральләре уза. Респ-каның көнбатышында бу ике юл Зөя–Буа–Ульянов, көнчыгышында Әгерҗе–Акбаш тимер юл линияләре б-н тоташтырылган. Татарстанның төп тимер юл төйнәлешләре — Юдино, Яшел Үзән, Әгерҗе, Круглое Поле (Чаллы шәһәре тирәсендә). Елга юллары Идел, Кама, Вятка, Агыйдел буйлап ТРның 17 районы аша үтә. Казанны РФ, якын һәм ерак чит илләр шәһәрләре б-н 50 дән артык һава юлы тоташтыра. 28 шәһәрдә һәм шәһәр тибындагы посёлокларда шәһәр эче пассажир автобуслары йөри, Казан, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә аларга — трамвай, Казанда һәм Әлмәттә — троллейбус, Казанда метро хәрәкәте оештэлә. Автобус хәрәкәте респ-каның 2200 ләп торак пунктын (70,8%) колачлый. Шәһәрләрдә 40 автовокзал һәм стационар касса пунктлары, шәһәрләрдә ш.у. таксилар хезмәт күрсәтә.

Респ-ка икътисадында үткәргеч торбалар транспорты мөһим роль уйный. Аның терр-ясеннән магистраль нефтьүткәргечләр уза.

Төбәкнең беренчел транспорт системасының нигезен ат юллары һәм парга нигезләнмәгән су транспорты төзи. Камада һәм Иделдә беренче пароходлар 1817 дә йөри башлый. 19 йөзнең 2 нче яртысында төбәк терр-ясендә *«Кавказ һәм Меркурий»*, *«Самолёт»* һ.б. акц. пароход компанияләре актив эшчәнлек алып бара. 1893 тә Мәскәү–Рязань тимер юл тармагы буенча Зөя станциясенә кадәр даими төстә пассажирлар һәм йөк ташу башлана. 1913 тә Казан губернасында барлык тимер юллар озынлыгы 249 *км*, елга юллары озынлыгы 840 *км* була, тимер юл транспорты б-н 140 мең *т*, су юлларыннан 737 *т* йөк озатыла.

1875 тә Казанда *атлы трамвай* (конка), 1899 да электр трамвайлары сафка кертелә. Беренче автомобильләр Казанда 1903 тә күренә башлый. 1917 дә Казан губернасында автомобильләр губерна һәм шәһәр хакимиятләре карамагында була, берничә машина Казан дары з-дында исәпләнә. Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышлары барышында транспорт системасы юкка чыга. Окт. рев-циясеннән соң бу тармак национализацияләнә (1918), үзәкләштерелгән идарә органнары төзелә. 1918–19 да Казан–Екатеринбург тимер юл линиясе бетерелә. 1924 тә Казан аэропорты ачыла, Мәскәүгә даими авиарейслар башланып китә. 1925 тә Казанда беренче автобус маршруты ачыла, 1930 да Казаннан шәһәрара автобус маршрутлары эшли башлый. 1927 дә Яшел Үзән–Йошкар-Ола тимер юл линиясе файдалануга тапшырыла, нәтиҗәдә, тимер юллар күбесенчә транзит рәвешен ала. Тупиктагы Казан станциясе 1928 дә көнбатыш юнәлештә турыдан-туры тимер юл магистраленә чыга. 1938 дә Казанда беренче таксилар йөри башлый. 1939 да респ-ка терр-ясендә файдаланудагы тимер юллар озынлыгы 392 *км* була, елына 1469 мең *т* йөк ташыла. 1940 та Казаннан ТАССРның 12 районына даими авиация юлы ачыла. Респ-када 3 меңнән артык автомобиль (шуларның 80 е автобус) исәпләнә.

Сугыштан соң автомобиль транспорты кызу темплар б-н үсә башлый. Автомобиль юллары яңадан торгызыла, транспорт парки яңартыла һәм тулыландырыла. Респ-када махсуслаштырылган зур йөк һәм пассажир пр-тиеләре төзелә һәм автомобильләрдән файдалану нәтиҗәлерәк төс ала. 1970 еллар башына Казанны Татарстанның барлык шәһәрләре һәм район үзәкләре б-н автомобиль юллары тоташтыра. Шәһәр халкының артуы сәбәпле троллейбус хәрәкәте үсеш ала (1948 дән). 1971 дән Бөгелмә–Круглое Поле тармагы буенча поездлар йөри башлый (соңрак бу юл Әгерҗе станциясенә кадәр озынайтыла). Яңа тимер юллар төзү б-н беррәттән, булганнарына да техник реконструкция ясала: районара төп магистральләр ике юллы итеп үзгәртелә (Канаш–Юдино–Кизнер юлы участоклары), сигнал, блокировка чаралары б-н җиһазландырыла һ.б. Локомотив паркы куәтле электровозлар б-н тулыландырыла. Елга флотын техник яктан ныгыту һәм су юлларын реконструкцияләү эшләре дәвам иттерелә. Нефтьне елга транспорты б-н ташу күләме даими арта. 1950 елларның 2 нче яртысыннан респ-када парга көйләнгән судноларны куәтле теплоходлар, дизель электроходлары, су асты канатлы тиз йөрешле теплоходлар («Ракета», «Метеор-2» һ.б.) алыштыра башлый, йөзмә краннар, елга төбен тирәнәйтү снарядлары яңартыла, хезмәт күрсәтү терр-ясе киңәя. 1957 дә Казанда заманча гидротехник саклау чаралары, йөк механизмнары, елга вокзалын үз эченә алган яңа *елга порты* төзелеп файдалануга тапшырыла. 1970 елларда Чаллы һәм Чистай пристаньнары портлар итеп үзгәртелә. 1990 елларга йөк һәм пассажирларны елга транспорты б-н ташу күләме 1960 еллар б-н чагыштырганда тиңдәшле рәвештә 4,3 һәм 2,6 тапкыр арта. Илнең төрле шәһәрләренә яңа даими авиарейслар ачыла, Казанда (1954), Чистай шәһәрендә (1957), Актаныш авылында (1958), Бөгелмә шәһәрендә (1960) яңа аэровокзаллар төзелә, 1971 дә — «Бигеш» аэропорты (Чаллы, Түбән Кама, Зәй шәһәрләренә хезмәт күрсәтү өчен), 1979 да Казанда яңа аэропорт файдалануга тапшырыла. Нефть һәм иярчен



Казансу аша «Миллениум» автомобиль күпере. Казан.



Балык Бистәсе районы Саескан Тавы авылы янында Кама елгасы аша салынган автомобиль күпере.



Ике катлы юл-транспорт чишелеше. Казан.

газ чыгару һәм эшкәртүнең югары темплары үткәргеч торбалар транспортын үстерүгә китерә. «Дуслык» (Әлмәт шәһәреннән башлана) үткәргеч торбасы, Урал–Себер һәм төньяк-көнбатыш юнәлешләрендә үткәргеч торбалар төзелә. 1990 елларга кадәр пассажирлар һәм йөк ташу даими үсештә була.

1990 еллардагы икътисади реформалар чорында транспортның тимер юллардан тыш барлык төрләре хосусыйлаштырыла, дәүләт көйләве б-н хуҗалык идарәсе функцияләре бүленә. Кече һәм урта бизнес, шәхси эшмәкәрлек шактый үсеш ала. Хезмәт күрсәтү тарифларын транспорт хуҗалары билгели башлый, көйләнүле тарифлар шәһәр һәм шәһәр яны җәмәгать транспорты секторында һәм табигый монополияләрнең кайбер төр хезмәтләренә генә саклана. Базар реформалары транспорт куллана торган ресурсларга бәяләр арту б-н бергә барганлыктан, йөк һәм пассажирлар ташу бәяләре дә күтәрелә һәм аларның күләме шактый кими (к. 4 нче табл.). Тузган төп фондларны яңарту проблемасы туа. 1990 елларда барлык транспорт төрләренең төп фондларының 50% ы тирәсе (авиациядә 70% ка кадәр) туза. 2000 еллар башына кризислы үсеш чоры туктатыла. Тимер юлларның хәрәкәттәге паркы уңайлы вагоннар, ерак һәм шәһәр яны юллары өчен тиз йөрешле һәм арзанлырак составлар б-н тулыландырыла. Арча, Буа, Зөя, Каратун, Килдураз һ.б. станцияләрдә вокзаллар төзелә һәм үзгәртеп корыла, пассажир платформалары төзелә. 2000 елларда елга порты инфраструктурасын яңартып кору буенча зур чаралар тормышка ашырыла, пассажирлар өчен күп кенә яңа су юллары ачыла һәм яңадан торгызыла, 2007 дә беренче тапкыр пассажирларны кышын һава мендәрендәге судноларда ташу башлана. Респ-ка аэропортларында күтәрелү полосалары модернизацияләнә һәм озынайтыла; «Казан» аэропортында 1,2 млн. пассажир үткәрү сәләтле терминал төзелеше төгәлләнә; «Бөгелмә» аэровокзалының яңа бинасы төзелә (2010). 2005 тә Казанда шәһәр транспортының яңа төре — *метрополитен* ачыла; соңгы елларда халыкка җәмәгать транспортында хезмәт күрсәтүне яхшырту буенча зур эшләр алып барыла: автобус маршрутлары челтәре камилләштерелә, шәһәр үзәгендә трамвай юллары сүтелә, уңайлы автобус һәм троллейбуслар сатып алына, рейслар саны арттырыла, җәяүлеләр өчен юлны җир астыннан һәм җир өстеннән чыгу урыннары, ике катлы юл-транспорт чишелешләре төзелә. Авиация һәм тимер юл транспортында билетлар сатуның, пассажирлар һәм багаж теркәүнең автоматлаштырылган системалары, транспортта йөрү өчен электрон документлар актив төстә гамәлгә кертелә. Милли «Мәгариф» проектын гамәлгә ашыру кысаларында респ-када укучы балалар мәктәпкә махсус автобусларда йөртелә.

Автомобиль юлларын, юллар инфраструктурасын үстерү һәм камилләштерү буенча зур эшләр алып барыла. Күперләр, ш.и. ТРда иң зур — Балык Бистәсе р-ның Саескан Тавы авылы янында Кама елгасы аша күпер салына (1 нче чираты 2002 дә, 2 нче чираты 2016 да), ул респ-каның 16 районын тоташтыра; Казанда асылмалы «Миллениум» күпере төзелә. 2013 тә М-7 «Идел» автомобиль юлында Вятка елгасы күперен реконструкцияләү төгәлләнә. Авыл торак пунктларына килү юлларын төзү өстенлекле юнәлеш булараk гамәлгә ашырыла. 1990–2015 елларда 5 мең *км* тирәсе гомуми кулланылыштагы каты түшәмәле юллар салына, «Көнбатыш Европа – Көнбатыш Кытай» транспорт коридоры составындагы Шәле–Баулы автомобиль юлы участогында хәрәкәт ачыла, М-7 «Идел» Мәскәү–Уфа юлының Казан–Чаллы участогында реконструкцияләү эшләре алып барыла. 2014 тә транспортта эшләүчеләр саны — 80 меңнән артык кеше (респ-ка икътисадында эшләүчеләр санының 6% ы). Тармакта 142,7 млрд. сумлык төп фондлар туплана (икътисадтагы төп фондлар бәясенең 10,2% ы). Халыкка 39,2 млрд. сумлык түләүле хезмәт күрсәтелә (респ-кадагы барлык түләүле хезмәтләрнең 17% ы). Төп капиталга 40,8 млрд. сумлык инвестиция салына (респ-ка инвестицияләренең 7,5% ы).

Гомуми кулланылыштагы барлык транспорт төрләре б-н ташылган йөк 70,9 млн. *т*: үткәргеч торбаларда — 20%, автомобильләрдә — 65%, эчке су юлларында — 5%, тимер юлларда — 15,7%; ташылган пассажирлар 449,2 млн. кеше: автобусларда — 73%, трамвай, троллейбуста — 18%, җир асты юлларында — 6,8%, тимер юлларда — 2%, эчке су юлларында — 0,1%, һава юлларында — 0,1% (2014).

Тармакның иң зур пр-тиеләре: *Горький тимер юлының Казан бүлеге* — «Россия тимер юллары» АҖ ф-лы, «Содружество» АҖ (шәһәр яны тимер юлларында ташу), «Татфлот» суднолар компаниясе, «Метроэлектротранс» (Казан), «Урта Идел Транснефтепродукт», «Татнефтьтранс», «Газпром Трансгаз Казань», «ЮВТ АЭРО» авиакомпаниясе, «Тататвтотранс» корпорациясе, «Кама алды Транснефть» һ.б.

*Әд.:* Фурьер Л.Н., Лукьянов Г.М., Синицина К.Р. Речники Татарии. К., 1977; Синицина К.Р., Тутаева М.З., Ахметов А.Н. Автомобильный транспорт Татарии. К., 1987; 100-летний юбилей Казанской железной дороги. К., 1995; 100 лет Казанскому трамваю. К., 1999.

**Элемтә.** Элемтәнең иң элгәрге төре — почта элемтәсе (к. *Почта*). Казанда беренче телеграф станциясе 1859 да, беренче телефон линиясе 1881 дә ачыла; 1888 дә — *Казан шәһәр телефон челтәре*, 1906 да *шәһәрара телефон элемтәсе* эшли башлый. 1917–18 дә элемтә чаралары, национализацияләнеп, Почта һәм телеграфлар халык комис-ты карамагына күчерелә. Почта пр-тиеләренә вакытлы матбугат тарату эше йөкләнә. 1918 нең мартыннан *Казан радио кабул итү-тапшыру станциясе* эшли башлый, 1927 дән даими радиотапшырулар алып барыла. Татарстанда массакүләм радиолаштыру 1928 дән башланып китә. 1930 да 3,1 мең радиотрансляция ноктасы эшләсә, 1990 га аларның саны 1330,2 меңгә җитә. 1923 тә СССР ХКСы каршындагы Татарстан ОГПУсы карамагында фельдъегерьлык хезмәте төзелә. Вакытлы

*4 нче таблица*

1950–2013 елларда ТРда гомуми файдаланудагы транспорт төрләре буенча йөкләр (млн. *т*) һәм пассажирлар (млн. кеше) ташу

| Транспорт төре | | 1950 | 1960 | 1970 | 1980 | 1990 | 2000 | 2010 | 2013 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Автомобиль | йөкләр | 0,1 | 11,8 | 23,9 | 55,0 | 45,2 | 11,9 | 21,8 | 23,7 |
| | пассажирлар | 5,1 | 111,4 | 242,3 | 589,6 | 806,0 | 707,5 | 410,7 | 303,1 |
| Тимер юл | йөкләр | ... | 12,1 | 14,4 | 21,8 | 19,8 | 10,0 | 10,0 | 15,7 |
| | пассажирлар | ... | 13,0 | 25,9 | 38,3 | 42,3 | 18,6 | 10,0 | 9,4 |
| Елга | йөкләр | ... | 9,9 | 25,9 | 35,3 | 42,9 | 6,9 | 8,7 | 10,7 |
| | пассажирлар | ... | 2,2 | 5,1 | 5,3 | 5,7 | 1,0 | 0,8 | 0,4 |
| Һава | пассажирлар | ... | 0,3 | 1,2 | 1,7 | 1,8 | 0,3 | 0,9 | 1,4 |

матбугатка яздыру һәм аны ваклап сатуны оештыру максатында 1932 дә «Союзпечать»нең респ-ка бүлекчәсе оештырыла. 1959 да Казаннан даими телевидение тапшырулары алып барыла башлый.

2000 елларда мәгълүмат-коммуникация технологияләренең (МКТ) Россия базары формалаша һәм ныклы үсеш ала; аның барлык сегментларына хезмәт күрсәтә торган компания һәм фирмалар бергәлеге оеша. 1998–2008 дә бу тармак элемтә хезмәте күрсәтүнең 20 дән артык төрдәге яңа технологияләрен үзләштерә. 1990 еллардан *Интернет* челтәренең респ-ка сегменты уңышлы үсеш ала, аннан файдаланучылар саны 900 мең кешедән артык (2013). 2007 дә «Электрон почта» федераль программасын гамәлгә ашыру барышында «Кибер Почт@» проекты кысаларында респ-када 70 тән артык Интернетка күмәк керү пункты оештырыла. Универсаль элемтә хезмәтләре программасын гамәлгә кертү чорында ТР терр-ясендә 3243 универсаль таксофон куела һәм 968 Интернетка күмәк керү пункты ачыла (2013), шул рәвешчә телефон кертелмәгән торак пунктлар б-н элемтә мәсьәләсе хәл ителә. Респ-ка шәһәрләрендә һәм район үзәкләрендә Интернетка 4G технологиясе буенча үткәргечләрсез керү челтәрләре үстерелә бара. 2012 ел башыннан ТРда цифрлы телевидение тапшырулары башлана. Белгечләр әзерләүнең сыйфатын күтәрү максатында укыту процессына яңача укыту һәм заманча МКТ гамәлгә кертелә: дистанцион уку-укыту, мультимедиа, Интернет һ.б. 2009 дан «Татарстан Республикасында электрон мәгариф» электрон системасы үсеш ала, бу системага барлык мәктәпкәчә, урта һәм өстәмә мәгариф учреждениеләре кушылган. ТРның 10 мең оешманы колачлаган дәүләт интеграцияләнгән телекоммуникацияләр системасы гамәлгә кертелә. Электрон рәвештә дәүләт, муниципаль хезмәт күрсәтүләр сферасы үсеш кичерә. 2012 дә респ-када яшәүчеләр шундый хезмәтләрдән 12 млн. тапкыр файдалана. ТР ачык хөкүмәт системасын гамәлгә кертүгә башлангыч бирә. «ГлонАСС» системасын кулланулы спутник, навигация технологияләре киң күләмдә тормышка ашырыла. 2013 тә ул система б-н 3 меңнән артык транспорт чарасы, мәктәп автобуслары, Гадәттән тыш хәлләр, Эчке эшләр, Сәламәтлек саклау министрлыклары һ.б. җиһазландырыла. 1990 елларның 2 нче яртысыннан радиотелефон элемтәсенең кәрәзле челтәрләре, персональ радиоэлемтә (пейджинг) челтәрләре һәм *спутник элемтәсе* системалары актив гамәлгә кертелә бара. Кәрәзле хәрәкәтчән элемтә челтәрләре аеруча динамик үсеш кичерә (к. *Телефон челтәре*): төп операторлар — «Ростелеком», «Мегафон», «Вымпелком», «НСС-Поволжье», «СМАРТС», «МТС» АҖләре. 2013 тә кәрәзле элемтә абонентларының саны 6739,5 мең кешегә җитә, аның тыгызлыгы 1000 кешегә 1755 номер тәшкил итә.

Респ-када гомуми кулланылыштагы зона автомат телефон элемтәсенең иң эре операторы — «Таттелеком» АҖ. Халыкның йорт телефоннары б-н тәэмин ителеше — 100 гаиләгә 58,7 данә. Шәһәрара һәм халыкара автомат телефон элемтәсе хезмәтен «Ростелеком», «Межрегиональный ТранзитТелеком», «Компания ТрансТелеКом» АҖләре һ.б. гамәлгә ашыра. Респ-када 10 оператор почта хезмәте күрсәтә. 2013 тә тармакта 19,3 мең кеше эшли. Төп капиталга 6,4 млрд. сум инвестиция салына (Татарстан икътисадына салынган барлык инвестицияләрнең 1,2% ы). Элемтәнең төп җитештерү фондларының бәясе 59,9 млрд. сум, элемтә хезмәтеннән алынган керем 32,3 млрд. сум тәшкил итә (элемтә хезмәтенең гомуми керемендә: почта кереме — 6,9%, шәһәрара һәм халыкара телефон элемтәсе — 4,3%, җирле телефоннар элемтәсе — 11,5%, күчмә электр элемтәсе кереме 46,0% алып тора).

*Әд.:* Б е л и х о в Д.С. Историко-статистический очерк телеграфного и телефонного дела в России вообще и в Казанском почтово-телеграфном округе в особенности. К., 1886; О р л о в а А.Ф. Время и связь. К., 1988; Р е й м а н Л.Д., Г о г о л ь А.А., Н и к о д и м о в И.Ю. Развитие связи в России. Из истории в будущее. СПб., 2001; Людей связующая нить. К., 2003.

**Агросәнәгать комплексы (АСК).** АСК ТРда халыкны азык-төлек б-н тәэмин итүдә әйдәп баручы роль уйный. Ул а.х. пр-тиеләрен һәм оешмаларын тәэмин итүче а.х., әзерләү, эшкәртү, продукция сату (азык-төлек, сөт, ит, катнаш азык һ.б.) пр-тиеләрен үз эченә ала. А.х. төп җитештерүче булып санала; респ-ка ТТПы структурасында аның өлеше 7,9% (2014), Татарстанда а.х.ның нигезен үсемлекчелек, башлыча, *бөртекле ашлык хуҗалыгы* тәшкил итә. Шулай ук *бәрәңге үстерүчелек, яшелчәчелек, чөгендер үстерүчелек, терлек азыгы* җитештерү һ.б. үсеш алган. Терлекчелеккә мөгезле эре терлек, *дуңгыз асраучылык, кошчылык, ат асраучылык, сарык асраучылык, умартачылык, җәнлекчелек, балыкчылык* керә.

Тармак структурасында а.х. продукциясен җитештерү 2013 ел нәтиҗәләре буенча үсемлекчелеккә — 48,9% (ш.и. бөртекле культуралар — 10,9, бәрәңге — 12,3, яшелчә культуралары — 10,6, яшелчә-җимеш — 4,2, терлек азыгы культуралары — 6,4, техник культуралар — 3,1%), терлекчелеккә — 51,1% (ш.и. терлекчелек һәм кошчылыкка 28,1, сөт — 18,5, йомырка — 2,0%) туры килә.


Татарстанда а.х. үсешенең иң түбән төшкән чорлары Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышлары, *«хәрби коммунизм»* сәясәте, крәстиян хуҗалыкларын күпләп *күмәкләштерү* башлану (1929–33), Бөек Ватан сугышы (1941–45), *колхоз* һәм *совхозларны* эреләндерү (1950–60), соц. хуҗалык итү ысулыннан базар икътисадына күчүнең башлангыч (1991–99) чорларына туры килә. А.х. җитештерүенең күтәрелеше респ-када НЭП чорына, КПСС ҮКның сентябрь (1953) һәм март (1965) пленумнарыннан соң, 2000 елларга туры килә.



«Агросила Групп» АҖнең «Чаллы-бройлер» ЖЧҖ кошчылык фабрикасы.

1920 дә, 1913 ел б-н чагыштырганда, бөртекле ашлык җитештерү — 3 тапкыр, бәрәңге өчтән бер өлешкә кими. 1928 дә а.х. культураларының чәчүлек мәйданнары, 1920 ел б-н чагыштырганда, 28,5% ка арта, ш.и. бөртеклеләрнеке — 25% ка, техник культуралар 53,7% ка, бәрәңге — 2,5 тапкыр, яшелчә 4,9 тапкыр арта; бөртекле ашлык җитештерү 2,7 тапкыр, бәрәңге 6 тапкыр арта. Крәстиян хуҗалыкларында 517,7 мең баш ат, 864,4 мең баш мөгезле эре терлек (ш.и. 461,3 мең баш сыер), 192,2 мең баш дуңгыз, 2626,6 мең баш сарык һәм кәҗә исәпләнә. А.х.н күмәкләштерү барышында 1935 кә, 1929 ел б-н чагыштырганда, атларның баш саны — 205,7 мең башка (38%), сыерлар — 141 мең башка (30,2%), сарыклар һәм кәҗәләр 2158,5 мең башка (3 тапкыр) кими. 1950 еллар уртасына а.х.н сугыштан соңгы торгызу, нигездә, тәмамлана. 1940–60 елларда а.х. культураларының чәчүлек мәйданнары — 10,8% ка, бәрәңгенеке — 30% ка, терлек азыгы культураларыныкы — 3,3 тапкыр; бөртекле ашлыкның тулай җыеме — 25,3% ка, бәрәңгенеке — 2,2 тапкыр, яшелчәнеке 6% ка арта. Шикәр чөгендерен, силос һәм яшел азык өчен кукурузны күпләп үстерү башлана; Мөгезле эре терлекнең баш саны — 43,5% ка (ш.и. сыер-





Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтының тәҗрибә кырлары:
1. Язгы бодай кыры; 2. Карабодай кыры.



Мөслим районы кырларында «Агромастер» җитештерү компаниясенең «Агромастер 8500» чәчү комплексы. 2009.



Буа районында шикәр чөгендере уңышын җыю. 2009.

лар — 30,1% ка), дуңгызлар — 3,1 тапкыр, сарыклар һәм кәҗәләр — 72,6% ка; ит җитештерү (тере үлчәмдә) — 2,9 тапкыр, сөт — 2,2 тапкыр, йомырка — 2,5 тапкыр, йон 73% ка арта. 1960 елларның 2 нче яртысыннан 1990 еллар башына кадәр а.х. җитештерүен үстерүгә капиталь кертемнәр даими арта бара. Респ-ка буенча гомуми капитал кертемнәр күләмендә аларның өлеше арта: 1965 тә — 5,4%, 1970 тә — 7,2%, 1980 дә — 9%, 1985 тә — 10,1%, 1990 да — 18,2%. Бу чорда респ-каның аграр секторы механикалаштыру, химияләштерү, мелиорация кебек интенсив факторлар хисабына үсә. А.х. пр-тиеләренең машина-трактор парклары сан һәм сыйфат ягыннан яхшыра. Тракторлар саны 11,2 меңнән 35,5 мең данәгә, бөртекле ашлык җыю комбайннары 8 меңнән 14,5 мең данәгә җитә. 1970–95 тә төп җитештерү потенциалы, ш.у. минераль ашламалар б-н тәэмин итү 4 тапкыр үсә. 283,1 мең *га* сугарулы, 23,9 мең *га* киптерелгән җирләр файдалануга тапшырыла; «Нармонка» (Лаеш р-ны), «Ворошилов», «Весенний» (Тукай р-ны), «Майский», «Овощевод» (Яшел Үзән р-ны), «Октябрь бүләге», «Түбән Кама» (Түбән Кама р-ны) кебек ачык грунтлы зур яшелчәчелек хуҗалыклары оештырыла. Чаллы, Түбән Кама шәһәрләре янында шәһәр яны а.х. зоналары булдырыла; мөгезле эре терлекләр өчен яңа фермалар, дуңгызчылык комплекслары, кошчылык ф-калары төзелә һәм элек эшләгәннәре яңартыла. 1960–90 елларда мөгезле эре терлекнең баш саны — 82,3% ка (ш.и. сыерлар — 39% ка), дуңгызлар — 53,8% ка, ит сатып алу — 5,8% ка, сөт — 4,9 тапкыр, йон җитештерү — 2,9 тапкыр, йомырка — 59,8% ка; а.х. продукциясенең тулай бәясе — 81% ка, ш.и. терлекчелек продукциясе 88% ка арта.

Хуҗалык итүдә базар алымнарына күчүнең башлангыч чоры а.х. җитештерүе үсешенә тискәре тәэсир итә. 1990–2000 елларда мөгезле эре терлек саны — 424,3 мең башка (26,3%, ш.и. сыерлар — 53,7 мең башка, 9,5% ка), дуңгызлар — 351,4 меңгә (31,8%), сарыклар һәм кәҗәләр — 999,5 мең башка (3 тапкыр); ит җитештерү — 40,2% ка, сөт — 19,4%, йомырка — 19,6% ка, йон җитештерү 3 тапкыр кими. Тракторлар саны — 35,5 меңнән 29,5 меңгә, бөртекле ашлык җыю комбайннары 14,5 меңнән 8,3 меңгә кадәр азая.

1990–2000 елларда а.х. җитештерүенең колхоз-совхоз системасы үзгәртеп корыла һәм аның җирлегендә яңа оештыру формасындагы а.х. пр-тиеләре барлыкка килә. 2013 тә 321 зур һәм урта а.х. пр-тиесе кала, шулардан 270 ҖЧҖ, 31 а.х. җитештерү кооперативы, 21 АҖ, 2 колхоз, 3 унитар пр-тие. Шулай ук 271,1 мең *га* җир кишәрлеге булган 2670 крәстиян (фермерлык) хуҗалыгы теркәлә. 113,4 мең *га* мәйданда 446,5 мең гаиләнең йорт яны кишәрлекләре, 28,9 мең *га* мәйданда 383,6 мең гаиләнең шәхси бакчасы, 0,6 мең *га* мәйданда 4,2 мең гаиләнең коллектив һәм шәхси бакчалары була.

Нәтиҗәдә, авыл хуҗалыгындагы үзгәртеп кору алга таба үсеш ала. 2014 тә 511 зур һәм урта а.х. пр-тиесе исәпләнә, шуларның 356 сы — ҖЧҖ, 21 е — а.х. җитештерү кооперативы, 22 се — АҖ, икесе — колхоз, берсе — унитар пр-тие. Шулай ук 276,6 мең *га* җир участогы булган 1508 крәстиян (фермерлык) хуҗалыгы теркәлә. 448,1 мең гаиләнең 113,7 мең *га* йорт яны җир кишәрлеге, 385,9 мең гаиләнең 30 мең *га* коллектив (кумәк) һәм шәхси җиләк-җимеш бакчасы, 4,2 мең гаиләнең 0,6 мең *га* коллектив (кумәк) һәм шәхси яшелчә бакчасы була.

2014 тә а.х.нда 4538 мең *га* а.х. файдалану җирләре, ш.и. 3430,0 мең *га* сөрүлек җирләр исәпләнә. А.х. файдалану җирләренең гомуми күләменнән 56,3% ы — а.х. оешмалары, 6,1% ы — крәстиян (фермерлык) хуҗалыклары һәм шәхси эшмәкәрләр карамагында, 36,1% ы — ярдәмче хуҗалыкларны, гражданнарның хезмәт кишәрлекләрен, коллектив (кумәк) һәм шәхси җиләк-җимеш бакчаларын, яшелчә бакчаларын, шәхси торак төзелешен, дача җирләрен һәм дача берләшмә-



«Чаллы икмәге» АҖ сортлы он тарттыру тегермәне. Чаллы шәһәре.

ләрен, җир өлеше хуҗаларын да кертеп — гражданнарның шәхси куллануында.

А.х. үсешендә уңай тенденцияләр 21 йөз башында күренә. Төп капиталга инвестицияләр арта: 2009 да — 277,6 млрд. сум, 2013 тә — 520,2 млрд. сумга кадәр үсә. Соңгы елларда респ-каның а.х. үсешенә аномаль һава шартлары тәэсир итә. Бөртекле культураларның уңышы 2009 да һәм 2013 тә 1 *га* дан 34,4 *ц* һәм 23,0 *ц*, бәрәңге — 197 *ц* һәм 181 *ц*, яшелчә — 274 *ц* һәм 399 *ц*, шикәр чөгендере 274 *ц* һәм 399 *ц* тәшкил итә; еллык савым һәр сыердан уртача 4572 һәм 4512 *кг* була. Тулай а.х. продукциясенең бәясе барлык категорияле хуҗалыкларда 117,3 млрд. сум тәшкил итә. А.х. хезмәткәрләренең уртача хезмәт хакы 13,4 мең сумга җитә.

Респ-ка климат шартлары уртача булган елларда 4,5–5 млн. *т* бөртекле ашлык, 2 млн. *т* дан артык шикәр чөгендере, 1,5 млн. *т* бәрәңге, 300 мең *т* яшелчә җитештерә.

2013 тә а.х. оешмаларында һәм фермер хуҗалыкларында бөртекле ашлык культураларының уңышы 2802,8 мең *т* тәшкил итә, бәрәңге — 1323 мең *т*, шикәр чөгендере — 2109,8 мең *т*, яшелчә — 329,4 мең *т*; 1712,2 мең *т* сөт һәм 475,6 *т* терлек һәм кош ите (тере үлчәмдә) җитештерелә. Мөгезле эре терлек 1029,9 мең баш (ш.и. сыерлар — 380,3 мең баш), дуңгызлар 547,7 мең баш, кошлар — 15,4 млн. баш тәшкил итә.

2013 тә а.х. оешмалары тарафыннан 1260,4 мең *т* бөртекле ашлык, 1581 мең *т* шикәр чөгендере, 52 мең *т* бәрәңге, 58,3 мең *т* май культуралары орлыгы, 340 мең *т* терлек һәм кош ите (тере үлчәмдә), 880 мең *т* сөт, 660,7 млн. данә йомырка сатыла.

2013 тә респ-ка бюджетыннан минераль ашламаларга, катнаш азыкка, дизель ягулыгына, үсемлекләрне саклау чараларына, тиз сроклы һәм инвестиция проектлары буенча процентлар түләүгә, лизинг буенча а.х. техникасы һәм нәселле терлек алуга, а.х. культураларын иминиятләштерүгә киткән чыгымнарның өлешен каплауга 7074,5 млн. сум субсидия бирелә, федераль бюджеттан 10628,8 млн. сум күләмендә акча керә.

А.х. культураларын үстерүдә дым саклаучы яңа технологияләрне нәтиҗәлерәк үзләштерү 2010 елгы корылык вакытында да уртача уңыш 1 *га* дан 11,2 *ц* булганда 0,7 млн. *т* бөртекле ашлык җитештерергә мөмкинлек бирә.

*5 нче таблица*

2000 һәм 2013 елларда а.х. продукциясен җитештерү, мең *т*

| Продукция исеме | 2000 | 2013 | 2013, % (2000 елга карата) |
|---|---|---|---|
| Бөртекле ашлык (башлангыч авырлыкта) | 3612,8 | 2802,8 | 77,6 |
| Шикәр чөгендере | 787,5 | 2109,8 | 267,9 |
| Бәрәңге | 909,1 | 1323,0 | 145,5 |
| Яшелчә | 228,8 | 329,4 | 143,9 |
| Терлек һәм кош ите (тере үлчәмдә) | 266,8 | 475,6 | 178,3 |
| Сөт | 1337,9 | 1712,2 | 127,9 |

А.х.н дәүләт-шәхси партнёрлык принципларында тизрәк үстерү өчен, респ-ка эчендәге стратегик инвесторлар — сәнәгать, банк һ.б. секторлардан компанияләр җәлеп ителә («Ак Барс» холдинг компаниясе», «Алтын башак» холдинг компаниясе», «Агросила Групп», «Кызыл Шәрекъ-Агро» АҖләре, «Бәхетле-Агро», «Союз-Агро» ҖЧҖләре), аларга (аренда хокукы нигезендә) респ-када якынча 50% сөрүлек җирләр һәм терлекләрнең баш саны беркетелә. 2000–2013 тә алар тарафыннан 300 дән артык терлекчелек объектлары, элеваторлар, катнаш азык һәм шикәр з-длары реконструкцияләнә һәм төзелә, заманча техника һәм җиһазлар куела (капиталь кертемнәрнең күләме 80 млрд. сум тәшкил итә). Россиядә һәм чит илләрдә җитештерелгән егәрлекле тракторлар, якынча 700 киң колачлы комплекслар һәм туры чәчә торган чәчкечләр сатып алына һәм гамәлгә кертелә. «Агромастер» чәчкеч комплексларын җитештерү җайга салына. Күп терлекчелек комплексларында һәм фермаларында инвесторлар агрофирмалары һ.б. а.х. оешмалары тарафыннан заманча саву агрегатлары куела; 45,5 мең баш нәселле мөгезле эре терлек, 20 мең баш нәселле дуңгыз сатып алына. Яңа комплекслар һәм мегафермаларны файдалануга тапшыру нәтиҗәсендә «Кызыл Шәрекъ-Агро» илдә иң зур сөт җитештерүче компаниягә әверелә.

2013 тә Актаныш р-нында инновацион ресурс саклаучы технологияләр җирлегендә елына 25 мең *т* ит җитештерүче кошчылык комплексы («Әнәк» агрофирмасы» ҖЧҖ), Тукай р-нында елына 43 мең *т* ит җитештерүче дуңгызчылык комплексы, Чаллыда сәгатенә 150 баш дуңгыз һәм 10 баш мөгезле эре терлек чалучы һәм ит җитештерүче пр-тие («Камский бекон» ҖЧҖ), Әгерҗе р-нында 2600 башка исәпләнгән товарлыклы-сөтчелек фермасы («Ак Барс» холдинг компаниясе), Лаеш р-нында рапсның май орлыгын җитди эшкәртү буенча җитештерү комплексы («Нәфис-Биопродукт» АҖ), Питрәч р-нында елына 1 млн. йомыркага исәпләнгән инкубатор («Ак Барс» кошчылык комплексы ҖЧҖ), Саба р-нында 280 баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән югары технологияле роботлаштырылган сөт комплексы («Нырты АХҖ» ҖЧҖ), Кайбыч р-нында («Казаньзернопродукт» АҖ) һәм Биектау р-нында («Бөреле» АҖ) 60 мең *т* сыешлы бөртекле ашлык эшкәртү комплекслары, Тукай р-нында сәгатенә 40 *т* катнаш азык җитештерүче завод («Агросила Групп» АҖ) файдалануга тапшырыла. Күп еллар эчендә беренче тапкыр респ-ка а.х.нда сарык һәм кәҗәләрнең баш саны арту күзәтелә. Саба р-нында кәҗә сөте җитештерү буенча 7800 баш кәҗәгә исәпләнгән терлекчелек комплексы төзелә. Сөт җитештерүнең котелгән еллык күләме 600 *т*.

Ит җитештерүгә «Чаллы-бройлер» ҖЧҖ, «Камский бекон» ҖЧҖ, «Саба» агрофирмасы» ҖЧҖ, «Авангард» ҖЧҖ, «Татспиртпром» АҖ, «Ак Барс-Әгерҗе» агрофирмасы» ҖЧҖ кебек зур комплекслар сизелерлек өлеш кертә.

Азык-төлек продукциясенең төп төрләрен җитештерүче һәм сәнәгый җитештерү пр-тиеләре үсешендә алга китеш бар, аларның гомуми саны 1990 да 128 дән 2000 дә 328 гә һәм 2013 тә 1071 гә кадәр арта.

2013 тә А.х. һәм азык-төлек министрлыгы, ТР Фермерлар ассоциациясе ярдәмендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү ком-ты тарафыннан Казанда күп функцияле «Казан» агросәнәгать паркы» технол. комплексы ачыла. Комплексның төп билгеләнеше — респ-ка а.х. җитештерүчеләрен үз производстволарын ачу, әзер продукцияне эшкәртү, саклау һәм сату өчен тиешле база б-н тәэмин итү.

*6 нчы таблица*

2000 һәм 2013 елларда ТР азык сәнәгате пр-тиеләре тарафыннан продукциянең төп төрләрен җитештерү, мең *т*

| Продукциянең исемлеге | 2000 | 2013 | 2013, % (2000 елга карата) |
|---|---|---|---|
| Ит һәм 1 нче категория субпродуктлар | 41,3 | 166,4 | 402,9 |
| Казылык | 13,5 | 24,8 | 183,7 |
| Атланмай һәм май пасталары | 17,5 | 12,9 | 73,7 |
| Аертылмаган сөт продукциясе | 160,6 | 359,7 | 223,9 |
| Сыр һәм сыр продуктлары | 12,1 | 15,7 | 129,8 |
| Үсемлек майлары | 9,1 | 106,7 | 1172,5 |
| Икмәк һәм икмәк-күмәч әйберләре | 263,0 | 180,9 | 68,8 |
| Макарон-токмач әйберләре | 9,0 | 3,3 | 36,7 |
| Шикәр, шикәр комы | 153,6 | 202,8 | 132,0 |
| Кондитер әйберләре | 33,6 | 50,1 | 149,1 |
| Спирт, мең *дал* | 3366,0 | 3425,2 | 101,8 |
| Сыра, мең *дал* | 26134,0 | 24298,0 | 92,9 |
| Алкокольсез эчемлекләр , мең *дал* | 3257,0 | 4193,0 | 128,7 |
| Маргарин продукциясе | 6,4 | 2,6 | 40,6 |
| Майонез | 3,5 | 198,4 | 5668,6 |
| Он | 871,6 | 274,2 | 31,5 |
| Ярма | 34,4 | 15,0 | 43,6 |
| Катнаш азык | 269,0 | 768,9 | 285,9 |

*Әд.:* Зыятдинов Ф.С. Ресурсный потенциал агропромышленного комплекса: анализ, оценка и эффективность использования. К., 2001; Якушкин Н.М. Экономическое воздействие государства на развитие аграрного сектора и его совершенствование в условиях рыночной экономики. К., 2003; Кучаева Б.И. Российское село в рыночных условиях. К., 2008.

**Торак-коммуналь хуҗалык (ТКХ).** Татарстан терр-ясендә торакларны беренче уңайлаштыру элементлары 19 йөзнең беренче утыз елына карый. Төбәктә беренче сууткәргеч 1833 елда Алабуга шәһәрендә төзелә. Казанда 500 дән артык кое була, 1874 тән су б-н үзәкләштерелгән тәэмин итү башлана; сууткәргеч юлларында су алу будкалары төзелә. 19 йөзнең 2 нче яртысында Чистай шәһәрендә дә сууткәргеч корыла. Көнкүреш калдыклары өчен шәһәр тышындагы җәмәгать җирләрендә махсус урыннар билгеләнә; кышын урамнардагы чүп һәм тирес бөтенләй диярлек җыелмый. 1899 да Казанда урамнарны чүптән чистарту һәм көнкүреш калдыкларын чыгару максатында даими шәһәр олаулары оештырыла. Черек күл тирәсендә яңгыр һәм кар суларын, урамнардан, ишегалларыннан чыккан агынты суларны төшерү өчен су агызу торбасы төзелә, аңа канаулар тоташтырыла. Урамнар явым-төшем вакытында пычрак, ә җәй айларында тузанлы булганлыктан, үтеп йөрү өчен шактый уңайсыз була, бу бигрәк тә үзәктән читтәге урамнарда сизелә. 1829 да урамнарга таш җәя башлыйлар; 1874 тә Казандагы барлык урамнарның 48% ына, ә 1896 да 65% ына (70 *км* тирәсе) таш түшәлә. 1850 елларда Казанның кайбер урамнарында киндер мае ягыла торган фонарьлар күренә башлый, 1874 тән газ б-н яктырту гамәлгә керә, 1897 дән шәһәр үзәге электр б-н яктыртыла. Шәһәрләрне төзекләндерү эше җирле үзидарә органнары, җәмәгатьчелек башлангычы б-н алып барыла. 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында ш.у. хосусый төзекләндерү эшчәнлеге дә күзәтелә.

1920 елларда коммуналь хуҗалык алга таба үсеш кичерә. 1923 тә өстенлекле кредит бирүче кооператив-торак төзелешенә ярдәм ком-ты булдырыла. 1923–26 да 16 мең $м^2$ торак һәм 338 шәхси агач йорт төзелә. 1930 елларда ТКХ үзгәртеп корыла. 1938 нең 1 гыйнварына ТАССР буенча җирле советларга караган йорт идарәләренең торак мәйданы 886,4 мең $м^2$, шулардан 777,4 мең $м^2$ торак Казанда була. Торакларны, ш.и. барак һәм тулай торакларны тиешле санитар-көнкүреш хәлenә китерү буенча зур эшләр җәелдерелә. Эшләп килүче су кудыру станцияләренең һәм эчәргә яраклы сууткәргечләрнең куәте арттырыла, яңа чистарту корылмалары төзелә, җылылык үткәрү буенча да зур эш башкарыла, Казанда сәнәгый сууткәргечнең 1 нче чираты эшли башлый; 1940 та сууткәргечләрнең озынлыгы 76,4 *км* га җитә. 1939 да 1 нче агынты суларны чыгару станциясе һ.б. файдалануга тапшырыла; канализация челтәренең озынлыгы 1932–40 та 5,2 *км* дан 48,2 *км* га кадәр арта. Шәһәрләрдә чисталык саклау максатында автоцистерналар, чүп чыгару машиналары, су сиптергеч машиналар файдаланыла башлый. Урамнарны яктырту эше дә алып барыла. 1940 еллар ахырыннан, массакүләм торак төзелеше башлану б-н, коммуналь хуҗалык системасы көчлерәк үсеш ала. Торакларны уңайлаштыру максатында фатирларны үзәкләштерелгән су б-н тәэмин итү, канализация, җылыту, кайнар су кертү һәм газлаштыру буенча төп чаралар күрелә. 1990 га респ-каның шәһәр һәм шәһәр тибындагы посёлоклары торак фонды сууткәргечләр б-н — 96% ка, канализация б-н — 94% ка, җылы су б-н — 69% ка, үзәкләштерелгән җылылык б-н 95% ка тәэмин ителә. 1980 еллар ахырыннан, базар икътисадына күчү бары-

шында, респ-када торакны хосусыйлаштыру башлана, 1989 да 327 фатир (0,1%) хосусыйлаштырыла. ТРның «Татарстан Республикасының торак фондын хосусыйлаштыру турында» Законы (1993) нигезендә шәһәр һәм пр-тиеләрнең торак һәм торак булмаган фондларын, алардан файдалана, хезмәт күрсәтә, карап тота һәм төзәтә торган инженерлык инфраструктурасы объектларын муниципаль милеккә күчерү башлана. 1990 елларның 2 нче яртысыннан халыкның яшәү шартларын сыйфатлырак итүгә, чыгымнарны киметүгә, торак һәм коммуналь хезмәт өчен түләү системасын йомшартуга юнәлтелгән ТКХ реформасы гамәлгә кертелә.

2014 нең 1 гыйнварына ТР торак фондының гомуми мәйданы 92,8 млн. $м^2$ тәшкил итә; торак фондта 1617965 фатир (шуларның 73% ы шәһәрләрдә) исәпләнә. Торак фондның 86,3% ы — гражданнар милке. Респ-када тузган һәм авария хәлендәге фондның гомуми мәйданы — 1223,7 мең $м^2$ (11595 йорт), торак фондның тузу дәрәҗәсе — 31% тан 65% ка кадәр (барлык мәйданның 27,3% ы) була. Торак фондның 87,7% ы — су үткәргечләр б-н (шәһәр җирендә — 96,3%, авылларда — 64,8%), 81,8% ы — канализация (94,9% һәм 47,1%), 96,9% ы — җылылык (99,1% һәм 91,2%), ш.и. үзәкләштерелгән җылылык б-н — 63,9%, кайнар су б-н — 73,7%, ш.и. үзәкләштерелгән кайнар су б-н 51,5% ы тәэмин ителә. Респ-ка буенча комплекслы уңайлаштырылган торакның өлеше уртача 73,7% тәшкил итә. Барлык шәһәрләрдә һәм шәһәр тибындагы посёлокларда, 2078 авылда (гомуми санның 67,8% ы) су үткәрү системасы эшли. Респ-када 2012 су алу объекты (Казанда 14, ш.и. «Волжский» — суны өстән алу) файдаланыла. Канализация системалары респ-каның барлык шәһәрләрендә, шәһәр тибындагы 17 посёлокта, 77 авылда эшли. Су б-н тәэмин ителеш ягыннан аеруча төзекләндерелгәннәр исәбенә Лениногорск, Сарман, Балтач, Спас р-ннары торак фондлары (100%, 95,4%, 93,4%, 93,4%) керә, су үткәрү системасы б-н иң яхшы җиһазландырылганнары — Тукай, Түбән Кама, Яшел Үзән, Лаеш р-ннары торак фондлары. ТР су үткәрү-канализация хуҗалыгында төп фондларның тузу дәрәҗәсе 49%. 1990–2000 еллар башында ведомство объектларын (котельныйлар һ.б.) муниципаль милеккә күчерү хисабына коммуналь энергетиканың җитештерү-техник базасы 20% тан күбрәккә арта. Халыкның җылылык энергиясенә ихтыяҗын 6 ТЭЦ, 2 ГРЭС, 1 ГЭС, 3 — район, 1932 сәнәгый һәм җылыту котельные тәэмин итә.

Түләүле хезмәт күрсәтүләрнең гомуми күләмендә торак-коммуналь хезмәтләрнең өлеше 24%, гамәлдәге тарифлар буенча халыкның әлеге хезмәтләр өчен түләү дәрәҗәсе 85,5%. Шәһәрләрдә халыкның торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү системасы гражданнарны адреслы социаль яклауны күздә тота. Түбән керемле гаиләләргә торак компенсацияләре (субсидияләр) программасы кабул ителә. Дәүләт (шәһәр) алдындагы аерым казанышлары өчен, һөнәри билгесе буенча, социаль билгесе (инвалидлар, ветераннар һ.б.) буенча гражданнарның төп өч категориясенә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә ташламалар халыкны социаль яклау формаларының берсе булып тора. 2013 тә ТРда 303710 гаилә (барлык гаиләләрнең 22% ы) ай саен уртача 562,8 сум ташламадан файдалана.

2003 тән башлап күп фатирлы торак йортлар б-н идарә итү һәм аларга хезмәт күрсәтүнең функцияләре аерыла; торак йортларга капиталь ремонт эшләре конкурс нигезендә гамәлгә ашырыла. Аерым эшләр өчен генә махсуслашкан оешмалар — гражданнарның торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрен исәпләүче хисап-касса үзәкләре; коммуналь хезмәт күрсәтүләрнең кулланылыш дәрәҗәсен исәпкә алучы приборларны урнаштыру һәм аларны карап тоту оешмалары булдырыла, һәм алар уңышлы эшләп килә. Барлык юнәлешләрдәге эшчәнлек муниципаль һәм хосусый оешмалар тарафыннан алып барыла. 37 меңгә якын күп фатирлы йорт идарәче компанияләр карамагында, 5859 дан артык йорт — торак милке хуҗалары ширкәтләре, 10 мең тирәсе йорт турыдан-туры милек ияләре карамагында.

2013 тә ТРда 814,5 мең $м^2$ мәйдандагы торакка капиталь ремонт ясала. Торак йортларга капиталь ремонт программасын финанслау күләме 4,8 млрд. сум тәшкил итә. Ш.у.к. *Су үткәрү челтәре, Торак хуҗалыгы, Торак реформасы.*

*Әд.:* З о р и н А.М. Города и посады дореволюционного Поволжья: Историко-этнографические иссл. населения и поселенческой структуры городов российской провинции второй половины XVI — начала XX вв. К., 2001.

**Банк эше.** Төбәктә беренче банк учреждениесе 1848 елда ачылган Казан шәһәр җәмәгать банкы була. Соңрак Казанда Россия Дәүләт банкы (1864), Идел-Кама коммерция банкы (1870), *Азов-Дон банкы* (1871) бүлекләре, Казан сәүдәгәрләр банкы (1873), ш.у. *Дворяннар җир банкы, Крәстияннәр җир банкы* һ.б. губерна икътисады үсешендә зур роль уйнаган банкларның бүлекләре эшли башлый. Октябрь рев-циясеннән соң Бөтенроссия ҮБКның 1917 ел 14 декабрь Декреты б-н банклар национализацияләнә; алар җирлегендә 1918 дә РСФСР Халык банкының Казан бүлеге төзелә. Респ-када СССР Дәүләт банкының бүлекчәсе 1922 дән — Казан өлкә конторасы, 1937 дән — Татарстан респ-ка конторасы, 1987 дән Татарстан респ-ка идарәсе буларак эшли. 1920–50 елларда ТАССРда кредитлар финанслау, җитештерүнең һәм җитештерүдән тыш өлкәләрнең төрле тармакларында исәп-хисап ясау, ш.у. халыкка хезмәт күрсәтү өчен күп кенә тармак дәүләт һәм кооператив банкларының бүлекләре — соңрак СССР Дәүләт банкы һәм СССР Төзелеш банкы бүлекчәләре итеп үзгәртеп оештырылган СССР Сәүдә-сәнәгать банкы, СССР А.х. банкы һ.б. респ-ка конторалары, ш.у. СССР Дәүләт хезмәт саклык кассаларының респ-ка идарәсе эшли. Нэп чорында ш.у. җирле банклар: Татарстан коммерция коммуналь банкы һәм Үзара кредитлашу хосусый җәмгыяте гамәлдә була. 1987–88 дә яңа оешкан «СССР Промстройбанкы», «СССР Агропромбанкы», «СССР Жилсоцбанкы», СССР Саклык банкының бүлекләре ачыла.

1990 елларда РФдә ике дәрәҗәдәге банк системасы: РФ Үзәк банкы (Россия банкы) һәм коммерция банклары барлыкка килә. Татарстанда беренче дәрәҗәгә Россия Банкының терр. учреждениесе — бердәм вертикаль идарә структурасындагы *Милли банк* керә. СССР Дәүләт банкының Татарстан респ-ка идарәсе 1990 нан — РСФСР Дәүләт банкының ТАССР буенча Баш идарәсе, 1992 дән ТР Милли банкы итеп үзгәртелә. 1994 тә «Россия хөкүмәтенең дәүләт хакимияте органнары б-н Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында»гы Шартнамә кысаларында банк эшчәнлеге өлкәсендәге килешүгә кул куела, килешү нигезендә ТР Милли банкының хокуклары шактый киңәя, аңа өстәмә вәкаләтләр, ш.и. халыкара сөйләшүләрдә Россия банкы вәкиле буларак эш итү хокукы бирелә. ТР Милли банкы респ-ка икътисадын үстерүгә ярдәм итә торган акча-кредит сәясәтен тормышка ашыра; коммерция банклары һ.б. учреждениеләр б-н кредит килешүләре төзи; эмиссия операцияләре үткәрүне тәэмин итә; респ-када акча әйләнеше торышын анализлый, аны ныгыту буенча тәкъдимнәр эшли; валюта операцияләрен контрольдә тота. Милли банкның 16 исәп-хисап касса үзәге, төбәк мәгълүматлаштыру үзәге бар.

Респ-када банк системасының икенче дәрәҗәсен коммерция банклары һ.б. кредит оешмалары бергәлеге формалаштыра. Коммерция банклары милекнең хосусый, дәүләти һәм катнаш формалары нигезендә төзелә. 2014 нең 1 гыйнварына ТРда активларының гомуми күләме 730 млрд. сумнан артык булган 22 коммерция банкы һәм аларның 66 ф-лы эшли. Керемнәренең күләме буенча «*Ак Барс*», «*Татфондбанк*», «Татсоцбанк», «Девон-кредит», «Интехбанк», «АКИбанк», «Аверс» банклары аеруча югары рейтингка ия. Акча әйләнешен рациональ оештыру, түләүләрне тәэмин итү һәм өстәмә ресурслар туплау юлы б-н респ-ка икътисадының үсешенә коммерция банклары актив булышлык итәләр.

*Әд.:* Банки и банковские операции. М., 1997; Банковское дело. М., 2000.

**Сәүдә һәм җәмәгать туклануы.** Борынгы заманнардан ук хәзерге Татарстан терр-ясендә товарлар алмашуның актив үсеше бу төбәкнең уңайлы геогр. урнашуы, судноларйөри алырлык елгалары булу (Идел, Кама, Зөя) б-н бәйле. Идел буе Болгар дәүләте Хәзәр дәүләте, Кавказ, Киев Русе, соңрак күрше рус кенәзлекләре, Балтыйк буе илләре, Урта Азия, Һиндстан, Византия һ.б. б-н сәүдә итә. Казан ханлыгы сәүдәгәрләре бу традицияләрне дәвам иттерәләр; Иделдәге «Маркиз» утравында ел саен үткәрелгән җәйге ярминкә халыкара сәүдә үзәкләренең берсенә әверелә, Казандагы *Ташаяк* ярминкәсе киң танылa. 18 йөздән сәүдә тагын да активрак үсә башлый. Беренче бөтендөнья сугышы, Гражданнар сугышы булу, СССРда ирекле сәүдәнең тыелуы сәбәпле, 20 йөз башыннан бу өлкәдә шактый дәрәҗәдә төшенкелек күзәтелә.

Сәүдә б-н, башлыча, дәүләт һәм кооперация органнары шөгыльләнә (нэп чорыннан кала), товарның 80% чамасы алар тарафыннан сатыла; бәяләр дәүләт тарафыннан билгеләнә. 1929–34 елларда, Бөек Ватан сугышы чорында һәм сугыштан соңгы беренче елларда товарлар карточкалар буенча бүлеп бирелә. Товар массасы арту б-н, яңа сәүдә пр-тиеләре күренә башлый. 1960–90 да аларның саны 7,3 меңнән 8,5 меңгә, эшләүчеләр саны 33,9 меңнән (1966) 61,1 мең кешегә җитә. Шул еллар бәяләре б-н исәпләгәндә ваклап сатулы товар әйләнеше 0,8 млрд. сумнан 5,1 млрд. сумга кадәр арта. Шулай булса да, совет чорында халык куллану товарларына кытлык кичерә. 1979–93 тә кайбер азык-төлек продуктлары һәм сәнәгать товарлары (мәс., юу чаралары) билгеләнгән куллану нормалары нигезендә талоннар буенча сатыла. Озак вакытка исәпләнгән товарлар (автомобильләр, суыткычлар, кер юу машиналары, телевизорлар, җиһазлар, паласлар һ.б.) чират тәртибендә бүленә.

1990 елларда сәүдә пр-тиеләрен хосусыйлаштыру һәм ирекле сәүдәгә күчү нәтиҗәсендә сәүдә эшмәкәрлеге киң җәелә, соңрак товар кытлыгы, чиратлар, талоннар буенча бүлү системасы юкка чыга, товарлар б-н тәэмин ителеш җанлана. Әмма 1990 еллардагы икътисади кризис аркасында халыкның сатып алу сәләте шактый түбәнәя. 1999 га тиңдәшле бәяләрдәге товар әйләнеше 1990 ел б-н чагыштырганда 23,3% ка кими, 2000 нән үсә башлый, 2002 дә элеккеге дәрәҗәсенә җитә, шуннан соңгы елларда югары темплар б-н үсә, 2005 тә 1990 ел дәрәҗәсен — 1,7 тапкыр, 2009 да 3 тапкыр узып китә.

1990 елларның 2 нче яртысыннан башлап, Татарстанның куллану базарында зур сәүдә компанияләре һәм пр-тиеләре: респ-кага караган — «Эдельвейс» сәүдә компаниясе», «Александр LTD», «DOMO» компанияләр төркеме» АҖләре, «Бәхетле» сәүдә галереясы», «Чистай «Универсалторг» күмәртәләп-ваклап сату предприятиесе», «Ак Барс Торг» («Пятёрочка» кибетләр челтәре), «Оптовик» («Эссен» челтәре), «ПИК» Сәүдә комплексы («Народный» челтәре), «Камилла» сәүдә йорты», «Агава» ҖЧҖләре һ.б.; федераль — «Перекрёсток» сәүдә йорты» («Перекрёсток», «Карусель» челтәрләре), «Тандер» («Магнит» челтәре), «Балалар дөньясы» һ.б. АҖләре; «Вестер-ритейл» («Вестер-гипер», «Сосед» челтәрләре), «Омега-97» фирмасы («Патэрсон» челтәре), «М-видео Менеджмент», «DIXIS» һ.б. ҖЧҖләре; чит илләр — «ИКЕА Мос» (сәүдә һәм күчемсез милек) (Швеция), «Метро КЭШ энд Керри», «Реал — Гипермаркет» (Германия) ҖЧҖләре һ.б. эшчәнлек җәелдерә. Заманча сәүдә һәм күңел ачу комплекслары («Мега», «*Тандем*», «XL»), гипер- һәм супермаркетлар төзелә; аларга заманча сәүдә җиһазлары куела, сатып алучылар өчен кинотеатрлар, рестораннар, кафе, уен заллары, балалар бүлмәләре һ.б. эшли. 2000 еллардан сәүдә системасына сатып алучыларга хезмәт күрсәтүнең иң яңа технологияләре һәм инновацион формалары, Интернет аша электрон сәүдә системасы гамәлгә кертелә башлый. Сәүдә инфраструктурасы (суыткычлар, складлар, саклау урыннары, транспорт, автомобиль кую урыннары) үсеш кичерә һәм өр-яңа җиһазлар, техника б-н җиһазландырыла. Клиентларның яшәү урынына якын, «бер адым ераклыктагы» сәүдә пр-тиеләре челтәре булдырыла; «Эдельвейс», «Перекрёсток», «Бәхетле», «Реал-Гипермаркет», «Омега-97» кебек компанияләрнең кайбер азык-төлек продуктларын җитештерү базасы бар.

*Сәүдә* (эчке һәм тышкы) өлешенә респ-ка тулай төбәк продуктының 15% ы туры килә.



«Suvar Plaza» сәүдә-офис үзәге. Казан.



«Тандем» сәүдә-күңел ачу үзәге. Казан.



Үзәк базар. Казан.



Үзәк базарның сәүдә рәте. Казан.

16 меңнән артык ваклап сату пр-тиесе эшли, шуларның 99% ы дәүләт милкенә карамый. 29 мең сәүдә урынына (азык-төлек, кием-салым, катнаш) исәпләнгән 100 дән артык базар эшли, аларда барлык товарның 9% тан артыгы сатыла (к. *Базар*). Сәүдә хезмәтендә 310 меңнән артык кеше (икътисади актив халыкның 17% ы) эшли. 2013 тә сәүдә әйләнеше (млрд. сумнарда): күмәртәләп сатуда — 1007,6, ваклап сатуда — 713. Респ-када бер кешегә кучереп исәпләгәндә 186 мең сумлык куллану товарлары (шуларның 42,7% ы азык-төлек) сатылган.

*Җәмәгать туклануы* системасында 200 ресторан, 1000 кафе, 120 җәмәгать ашханәсе, бистро тибындагы 700 кабымлыкханә, 60 кулинария кибете, 1700 мәктәп ашханәсе, сәнәгать пр-тиеләрендә һәм учреждениеләрдә 550 ашханә һ.б. — барысы 300 мең урынга исәпләнгән 5 мең тирәсе җәмәгать тукланыу пр-тиесе эшли. Бу тармакта эшләүчеләр саны — 20 меңнән арта. 2013 тә әлеге өлкәдә сәүдә әйләнеше 31,7 млрд. сум тәшкил итә: 2000 ел белән чагыштырганда бу 2,8 тапкыр (тиңләштерелгән бәяләрдә) артыграк.

### V. ТЫШКЫ ИКЪТИСАДИ ҺӘМ ТӨБӘКАРА ЭЛЕМТӘЛӘР

1980 еллар ахырыннан респ-ка җитәкчелеге дөньяның төрле илләре һәм аларның пр-тиеләре һәм оешмалары б-н партнёрлык бәйләнышлары урнаштыруда актив сәясәт алып бара. Германия, Франция, Италия, АКШ һ.б. Көнбатыш илләре б-н элемтәләр үсү б-н беррәттән, Төркия, Көньяк Корея, Япония, Һиндстан, Иран, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре һ.б. Көнчыгыш дәүләтләре б-н дә хезмәттәшлек ныгый.

1991 дән респ-ка хөкүмәте тарафыннан 50 дән артык халыкара килешүләр һәм беркетмәләр төзелә. Сәүдә-икътисад өлкәсендә РФнең 70 төбәге, БДБнең 8 иле һәм 17 ерак чит илләр б-н турыдан-туры килешү мөнәсәбәтләре урнаша. Респ-каның тышкы икътисади хезмәттәшлегенең дәрәҗәсен үстерүдә һәм тулыландыруда ТРның 1990 елларның 2 нче яртысында оештырылган РФдәге һәм чит илләрдәге (ерак чит илләрдә — 3, БДБ илләрендә — 5, Россиядә — 6) тулы хокуклы, даими һәм сәүдә-икътисад вәкиллекләре (к. *Татарстан Республикасының вәкиллекләре*) ин-ты шактый зур ярдәм күрсәтә.

2000 еллар башыннан сәүдә йортлары төзү эше киң җәелә, монда татар диаспорасының күренекле хуҗалык итүче субъектлары да инициатива күрсәтә. Россиядә: Мәскәү һәм С.Петербург шәһәрләрендә, Архангельск, Волгоград, Калининград, Түбән Новгород, Пенза, Самара, Саратов, Томск, Ульянов, Чиләбе, Ярославль өлкәләрендә, Башкортстан, Мордва респ-каларында, Ханты-Манси автономияле округында, Пермь краенда һ.б.да; ш.у. Латвиядә, БДБ илләрендә (Әзәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан) һәм ерак чит илләрдә (Иран, Төркия, Сингапур, Судан) 20 дән артык сәүдә йорты ачыла.

Тышкы икътисади элемтәләрне киңәйтүдә ТР дәүләт идарә органнары җитәкчеләренең чит илләргә даими визитлары, респ-каның икътисади куәте б-н таныштырулар,

дөньяның төрле төбәкләрендә эшлекле даирәләр б-н очрашулар, РФдәге чит ил дипломатик вәкиллекләре б-н эшләү, дәүләтара комиссияләр эшчәнлеге, Бөтендөнья банкы б-н хезмәттәшлек итү зур роль уйный. Төп пр-тиеләр — ТР экспортёрлары иң зур халыкара күргәзмә-ярминкәләрдә (бөтендөнья «ЭКСПО» күргәзмәсе, ел саен уздырыла торган Ганновер ярминкәсе, Якын Көнчыгыштагы «IDEX» хәрби техника күргәзмәсе һ.б.) даими катнаша.

1992–2013 тә респ-каның тышкы сәүдә әйләнеше 26 тапкыр арта. Товар экспорты күләме — 22,4 млрд., импорт 5,2 млрд. долларга җитә. Татарстан сәүдә өлкәсендә 130 ил, ш.и. Нидерланд (тышкы сәүдә әйләнешенең 23% ы), Италия (8,5%), Польша (9,6%), Белоруссия (8%), Төркия (4%) һ.б. б-н хезмәттәшлек итә. Респ-ка 120 илгә товар чыгара, 105 ил үзенең товарын кертә. Экспорт товарлары арасында эшкәртелмәгән нефть (78,3%), ясалма каучук һ.б. химия продуктлары (10,7%), транспорт чаралары, җиһазлар, приборлар (8,5%) өстенлек итсә, импорт товарларында машиналар, приборлар, җиһазлар, транспорт чаралары һәм аларның частьлары, узеллары һәм механизмнары (81%) зур урын били. Традицион импорт товарларына нефть химиясе продуктлары, кара металл һәм аннан эшләнгән торбалар, медикаментлар, алкогольле һәм алкогольсез эчемлекләр керә.

Тышкы икътисади эшчәнлектә инновацион хезмәт күрсәтү базары зур үсеш ала. Экспортка, нигездә, транспорт (28%), компьютер (17%), туризм (15%) өлкәсендә хезмәт күрсәтүләр чыга; инженерлык (17%), төзелеш (14%) хезмәтләре чит илдән кертелә. 2013 тә бу базарның күләме 4 тапкыр (ш.и. экспорт — 3 тапкырга) — 684,5 млн. долларга кадәр үсә. Респ-када хезмәт күрсәтү импорты — 559,5 млн., экспорт 125 млн. доллар тәшкил итә.

2000 елларда ТР РФнең барлык субъектлары (күбесенчә якын тирәләрдәге) б-н сәүдә хезмәттәшлеге алып бара. Ил базарына Татарстан машина төзелеше һәм металл эшкәртү товарлары: йөк автомобильләре һәм җиңел машиналар, диңгез һәм елга судналары, самолётлар, вертолётлар, компрессорлар, газ турбиналары, сан.-техник арматура, приборлар, мед. инструментлары һәм җиһазлары, нефть һәм химия җиһазлары, ш.у. полиэтилен, шиннар, каучук, поливинилхлорид сумала җибәрә. Читкә ш.у. ит һәм сөт продуктлары, ашлык, шикәр, аракы, сыра һ.б. азык-төлек чыгарыла. Импорт товарлары — кара металл прокаты, корыч торбалар, ясалма каучук, бензин; ит, ит продуктлары, кош ите, үсемлек мае, макарон әйберләре, алкогольле эчемлекләр һ.б. Экспорт һәм импорт товарларының тигезлеге саклана. Татарстанның РФ төбәкләре б-н сәүдә күләме 2008 дә — 260 млрд. сум, 2012 дә — 500 млрд. сум. Бу — респ-каның чит илләр б-н сәүдә күләменнән якынча 1,5 тапкырга кимрәк.

Респ-каның тышкы элемтә эшчәнлегендәге төп юнәлешләрнең берсе — 2000 елларда күләмнәре тотрыклы рәвештә арта барган чит ил инвестицияләрен җәлеп итү. 2010 да ТР икътисадына кертелгән чит ил капиталы иң зур күрсәткечкә — 4,1 млрд. долларга җитә, 2013 тә 0,9 млрд. доллар тәшкил итә. 2013 ел нәтиҗәләре буенча төп инвестор — Төркия (барлык чит илләр капитал салуының 24,5%ы), Германия (22%), Нидерланд (16%), АКШ (13%). 2014 ел башына Татарстан икътисадына чит илләр салган капитал күләме 4 млрд. тирәсе доллар тәшкил итә. Монда сәүдә һ.б. кредитлар (50%) зур роль уйный; пр-тие хуҗалары һәм милектәшләренең турыдан-туры инвестицияләре өлешенә — 36%, идарә итүгә хокуксыз («портфельле» инвестицияләр) кыйммәтле кәгазьләр сатып алу инвестицияләре өлешенә 9% туры килә. Төп тармаклар буенча җыелган инвестицияләр түбәндәгечә бүленә: ягулык-энергетика файдалы казылмаларын чыгару — 27,4%, төзелеш материаллары — 10,2%, химия җитештерүе — 9,8%, агач эшкәртү — 5,6%, нефть продуктлары — 5,1%, күчемсез милек б-н эшләү — 12%, төзелеш — 2,7%. Татарстан инвесторлары арасында иң эре транснациональ корпорацияләр: Италия «Teknimont» («Түбәнкаманефтехим» АҖдә яңа производство оештырыла), «LG International Corp» (яңа нефть эшкәртү комплексы төзелә), Япония «Mitsui & Co Ltd» (Казан «Органик синтез» ААҖдә яңа производстволар төзелә) корпорацияләре. ТРда инвестиция эшчәнлеген активлаштыруда Сәнәгый-җитештерү тибындагы «Алабуга» аерым икътисади зонасы мөһим роль уйный, шул сәбәпле резидент компанияләргә салым һәм таможня өлкәсендә күп кенә ташламалар бирелә.

Респ-када чит ил капиталы б-н эшләүче пр-тие һәм оешмалар эшчәнлеге киңәя. 2002–13 тә аларның саны 144 тән 474 кә җитә, эшләүчеләрнең саны 107,8 мең кешедән 127,4 мең кешегә кадәр арта. Мондый пр-тие һәм оешмалар аеруча Кипрда (87), Төркия (76), Германия (36), АКШ (25), Бөекбритания (19), Беларусь һәм Нидерландта (17 шәр), Казакъстанда (12) мөһим урын били; алар эшчәнлек өлкәләре буенча — сәүдәдә һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтүдә (55%), күчемсез милек б-н эшләүдә (13,5), эшкәртү тармагында (12,8), төзелештә (4,3) зур роль уйный.

Татарстан — инвестиция өлкәсендә ышанычлы төбәкләрнең берсе. «Standart & Poor's», «Moody's», «Fitch Ratings Ltd» халыкара әйдәп баручы рейтинг агентлыклары аның озак вакытка исәпләнгән югары рейтингын раслый.

Татарстаннан да чит илләргә инвестицияләр чыгарыла (2014 ел башына 398,9 млн. доллар тәшкил итә). Чит илләрдә, башлыча, БДБ илләрендә, күп кенә пр-тиеләр «Татнефть», КАМАЗ һ.б. б-н хезмәттәшлек итә.

## VI. СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ

Төбәктә беренче мед. учреждениеләре 18 йөз башында барлыкка килә. 1864 елга, земство үзидарәсе кертелү чорына, Казан губернасында 12 хастаханә, 1913 елга — 98 дәвалау учреждениесе, 1600 ятак-урынлы Казан округ психиатрия дәваханәсе, хәрби госпиталь (1809), 23 дәваханә һ.б. эшли. 1864 елгы Земство реформасыннан соң, социаль чыгышларына карамастан, губернада халыкның барлык катлауларына бушлай мед. ярдәме күрсәтү принципларына нигезләнгән *земство медицинасы* үсеш ала (1917 гә кадәр гамәлдә була). Совет хакимияте урнаштырылганнан соң, халыкка мед. хезмәте күрсәтү, кешеләрнең сәламәтлеген кайгырту дәүләтнең эчке сәясәтендә иң әһәмиятле юнәлешләренең берсенә әверелә. Мед. хезмәте күрсәтү системасы тамырдан үзгәртеп корыла: ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-ты (1920), җирле советларның башкарма ком-тлары каршында аның кантон һәм шәһәр бүлекләре оештырыла, *ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү хезмәте* тергезелә. Тиешле мед. ярдәмен һәр кешегә бушлай күрсәтү тәртибе саклана. 1920–30 елларда Казанда электән гамәлдә булган клиник хастаханәләр (хәзер В.С.Груздев, В.К.Меньшиков, Е.М.Лепский исем. клиникалар, Терегулов исем. 1 нче шәһәр клиник хастаханәсе (Шамов хастаханәсе), В.М.Бехтерев исем. Респ-ка психиатрия хастаханәсе), бала тудыру йортлары, стомат. поликлиникасы, балалар һәм хатын-кызлар консультацияләре (к. *Поликлиника*), 11 шәһәр хастаханәсе, сан.-эпид. хезмәте оешмалары, туберкулёздан дәвалау учреждениеләре: Каменка посёлогындагы санаторий, Юдинодагы «Зәңгәр күл» һәм Казан янындагы «Обсерватория» балалар санаторийлары эшли. Шул елларда клиникалары б-н ГИДУВ (к. *Казан медицина академиясе*, 1920; беренче директоры — Р.А.Лурия; *Казан медицина академиясе клиникалары*), Эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү ин-ты, Ортопедия һәм травматология фәнни-тикшеренү ин-ты, Туберкулёз һәм Трахома ин-тлары барлыкка килә. Профессорлар М.О.Фридланд, А.В.Вишневский, Л.И.Шулутко, Н.А.Семашко һ.б. фәнни тикшеренүләр алып бара. Урта мед. хезмәткәрләре мед., фарм. һәм фельдшер-акушерлар уч-щеләрендә әзерләнә. Казан ун-тының мед. ф-ты нигезендә 1930 да мед. ин-ты ачыла (к. *Казан медицина университеты*). 1930 еллар ахырына респ-када *сәламәтлек саклау* һәм мед. кадрлары әзерләүнең дәүләт системасы ныгып урнаша. Бөек Ватан сугышы елларында Казан эре хәрби-мед. үзәкләренең берсенә әверелә, анда 35 мең ятак-урынны берләштергән *эвакуация госпитальләре* эшли; мед. хезмәткәрләренең фидакарь хезмәте б-н яралыларның 70% тан артыграгы кабат сафка баса. Сугыш елларында хәзерләнгән мед. кадрлары һәм алар тарафыннан тупланган зур тәҗрибә 1950–60 елларда сәламәтлек саклау системасы эшчәнлеген алга таба камилләштерүдә мөһим роль уйный. 1968 дә респ-када — трахома, 1978 дә бизгәк авыруы бетерелә. 1970–90 да халыкка мед. хезмәте күрсәтүне үстерү өлкәсендә сизелерлек үзгәрешләргә ирешелә. Массакүләм дәрәҗәдә мед. хезмәткәрләренең белемен күтәрү оештырыла, сәламәтлек саклау учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуда яңа адымнар ясала: Респ-ка балалар клиник хастаханәсе (1974), Респ-ка клиник хастаханәсенең яңа корпуслары (1982) файдалануга тапшырыла; югары технологиягә нигезләнгән төбәкара, респ-ка һәм

шәһәр мед. үзәкләре (онкология, вертеброневрология, кардиохирургия үзәкләре), Респ-каның СПИДка каршы профилактика үзәге, Төбәкара клиник диагностика үзәге һ.б.) оештырыла. 1960–80 дә Казандагы фәнни, укыту-методик һәм дәвалау учреждениеләрендә колачлы тикшеренү эшләре алып барыла, аеруча киң таралган авыруларга диагноз кую һәм дәвалауның яңа, камилрәк ысуллары эшләнә, яңа дарулар б-н тәҗрибәләр уздырыла һәм алар гамәлгә кертелә. Фәнни тикшеренүләргә профессорлар М.З.Сигал, Г.А.Смирнов, А.Ю.Ратнер, О.С.Кочнев, Ә.Л.Латыйпов, Н.П.Медведев, Л.И.Шулутко, А.М.Потёмкина, Т.Б.Толпегина, Д.М.Зөбәеров, Б.Л.Мазур, И.В.Заиконникова, И.Ф.Харитонов, И.Г.Салихов, Р.А.Вяселев, Д.К.Бәширова, В.Ф.Богоявленский һ.б. җитәкчелек итә. 1970–80 дә А.А.Әхмәтҗанов, М.К.Михайлов, Н.Х.Әмиров, Л.А.Зефиров, Р.С.Гәрәев, А.Г.Җиһаншин, Д.М.Красильников, В.И.Данилов, Г.А.Иваничев, Р.Ш.Вәлиев, А.С.Созинов, В.Н.Медведев, Р.Ш.Хәсәнов, И.А.Гыйләҗетдинов, В.Х.Фазылов, В.А.Анохин, Д.Э.Цыплаков, М.М.Миңлебаев, В.Е.Григорьев һ.б. талантлы галим-тикшеренүчеләр үсеп чыга. 1980 еллар ахырында башланган үзгәртеп кору һәм 1990 еллар ахырындагы икътисади кризис мед. учреждениеләре төзү темпларының кимүенә, квалификацияле мед. белгечләренең респ-кадан читкә китүенә сәбәп була. Халык тормышының социаль-икътисади дәрәҗәсе төшү нәтиҗәсендә барлык төр авыруларның зур күпчелеген кискен йогышлы сулыш авырулары, грипп, вируслы гепатит, паразитар һәм социаль шартларга бәйле авырулар тәшкил итә. 2000 нән башлап сәламәтлек саклау өлкәсендә вазгыять уңай якка үзгәрә: медицинада илебездә һәм чит илләрдә эшләнгән камилрәк дәвалау-диагностика технологияләре гамәлгә кертелә башлый, Казанда, Әлмәттә яңа эре диагностика үзәкләре ачыла, йогышлы авырулар хастаханәсенең яңа бинасы (Казан), түләүле шәхси мед. учреждениеләре (стомат. поликлиникалары, консультация пунктлары, дәвалау кабинетлары һ.б.) төзелә; дәвалау учреждениеләренең матди-техник тәэмин ителешендә уңай үзгәрешләр була (к. *Сәламәтлек саклау*). Респ-ка сәламәтлек саклау системасында авыру очракларын кисәтү, халыкка мед. ярдәме күрсәтүнең сыйфатын яхшырту, ш.у. экологик тайпылыш нәтиҗәләренә, эчә торган суның һәм азык-төлекнең сыйфаты начараюга каршы көрәш мәсьәләләре актуаль төс ала.

Авыруларны кисәтү юнәлешендә санаторий-курорт оешмалары зур роль уйный: респ-када 8 санаторий һәм курорт (*«Васильево», «Жемчужина», «Ливадия», «Бәкер», «Иж минераль сулары», «Крутушка»,* «Санта», «Сосновый бор»); җитди авырулардан соң өстәмә дәвалау өчен реабилитация бүлекләре булган 40 санаторий-профилакторий; инвалид балалар, аналар һәм балалар, йөкле хатыннар өчен аерым санаторийлар бар. Дәвалауда минераль сулар һәм дәва ләме (30 дан артык файдалы су һәм ләм чыганагы, ш.и. «Бәкер» чыганагы тикшерелгән) киң кулланыла. Реабилитация чаралары кулланып, авыруларның хезмәткә сәләтлелеген тергезү һәм аларны актив тормышка кайтаруның нәтиҗәлелеге 85% тәшкил итә.

Хәзерге вакытта ТРда 150 дән артык дәвалау-профилактика учреждениесе (ш.и. Казанда һәм Чаллыда 2 ашыгыч ярдәм хастаханәсе), 58 амбулатория-поликлиника учреждениесе, 21 стомат. поликлиникасы, 8 диспансер бар; аларда 15 меңнән артык табиб, 40 меңнән артык урта мед. хезмәткәре эшли.

*Әд.:* Казанский медицинский институт. К., 1989; Казанский ГИДУВ им. В.И.Ленина. К., 1990; З ы я т д и н о в К.Ш., П а в л у х и н Я.Г. Очерки истории медицины Татарстана. К., 2005.

## VII. МӘДӘНИЯТ

**Халык мәгарифе**. Идел буе Болгар дәүләтендә, аннан соң Алтын Урда һәм Казан ханлыгында, мөселман традицияләре нигезендә, мәчетләр каршында дини мәктәпләр һәм *мәдрәсәләр* эшли. Халык арасында уку-язу гарәп графикасы нигезендә таралган була, җәмгыятьнең югары катлавында гарәп һәм фарсы телләре дә кулланыла. Казан ханлыгы таркалу нәтиҗәсендә мөселман мәгариф системасы бетерелә, әмма муллалар шәхси рәвештә балалар укытуны дәвам итәләр, аерым татарлар Урта Азиянең дини мәгариф үзәкләрендә укыйлар. Мөселман мәгариф традицияләре төбәктә 17 йөзнең 2 нче яртысыннан яңадан торгызыла башлый. Беренче мәдрәсәләр Бохарада белем алган мөгаллимнәр тарафыннан Ор (хәзерге Балтач р-ны, Юныс Иванай), Югары Симет (хәзерге Саба р-ны, Мортаза әс-Симети), Тайсуган (хәзерге Әлмәт р-ны) авылларында оештырыла. 18 йөзнең 2 нче яртысыннан мөселман мәгарифе сизелерлек үсеш ала, 19 йөзнең 1 нче яртысында мәчетләр каршында мәктәпләр ачыла, Казан һәм төбәкнең кайбер башка торак пунктларының мәдрәсәләре киң танылу ала (*«Касыймия», «Мәрҗания», «Кышкар», «Мәчкәрә»* һ.б.). Ләкин мөселман дини уку йортларында укыту дәрәҗәсе тормыш таләпләренә җавап биреп бетерми. 19 йөзнең 2 нче яртысында киң таралып, *җәдитчелек* исеме алган мәгърифәтчелек-реформаторлык хәрәкәте тәэсирендә күп кенә мөселман уку йортлары яңа ысул б-н укытуга күчә башлый. Яңартылган «Мөхәммәдия», «Бубый» мәдрәсәләре Россиядә дини һәм дөньяви фәннәрне югары дәрәҗәдә укыта торган зур мөселман уку йортларына әверелә. Казанда беренче дөньяви рус уку йорты — *цифирь мәктәбе* 18 йөз башында Адмиралтейство каршында эшли башлый, соңрак шундый мәктәп Зөя шәһәрендә булдырыла. 1723 елда дин әһелләре өчен славян-латин мәктәбе ачыла (1733 тә Казан руханилар семинариясе итеп үзгәртелә, 1798–1818 дә руханилар академиясе, 1818 дән яңадан семинария). 1730 еллар башыннан Казан, Зөя, Алабугада яңа керәшен мәктәпләре эшли башлый. 1758 дә Казанда Сенат фәрманы б-н провинциаль Россиядә беренче гимназия ачыла, ул төбәктә дөньяви белем бирүнең чын учагына әйләнә (к. *Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе*). 1786 да беренче гомуми мәктәп — Казан әсасый халык уч-щесе, 1796 да Чистайда кече халык уч-щесе ачыла. 1804 тә Казан ун-ты нигезләнә, ул тиздән Россиядә иң зур мәгариф һәм фән үзәкләренең берсенә әверелә. 1804–18 дә Бөгелмә, Буа, Алабуга, Мамадыш, Минзәлә, Зөя, Спас, Тәтеш, Чистайда өяз уч-щеләре эшли башлый. 1842 дә *Казан руханилар академиясе*, 1873 тә Казан вет. ин-ты ачыла (к. *Казан ветеринария медицинасы академиясе*).

Авыл җирлегендә беренче уку йортлары буларак 1843 тән *Дәүләт милке министрлыгы мәктәпләре* ачыла, 1860 еллар башына аларның саны 60 ка якынлаша.

19 йөзнең 2 нче яртысында гомуми белем бирү уку йортларының саны арта. Казанда 2 ир балалар гимназиясе (1835, 1870), 2 реаль уч-ще (1875, 1907), 3 кыз балалар гимназиясе (1859, 1870, 1905), 2 епархия уч-щесе (1868, 1890) ачыла. Реаль уч-щеләр Алабуга (1878), Бөгелмә (1903), Минзәләдә (1914) булдырыла, кыз балалар гимназияләре 1860 тан Алабугада, 1862 дән Минзәлә һәм Чистайда, 1903 тән Бөгелмәдә эшли башлый. 1899 да Алабугада епархия уч-щесе оештырыла.

1860 елларның 2 нче яртысыннан башлангыч мәктәпләр земство һәм шәһәр үзидарә органнары тарафыннан булдырыла, 1884 тән чиркәү-приход мәктәпләре, ш.и. руслар яшәмәгән торак пунктларда, күпләп ачыла башлый. 1867 дән рус авылларында *Изге Гурий борадәрлеге* һәм Православие миссионерлык җәмгыяте мәктәпләре эшли, 20 йөз башына якынча 100 шундый мәктәп була. Мәктәпләрнең квалификацияле укытучыларга ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен пед. уку йортлары: 1871 дә *Казан халык укытучыларын укыту земство мәктәбе*, 1872 дә *Казан укытучылар семинариясе*, 1876 да *Казан татар укытучылар мәктәбе* һәм *Казан укытучылар институты* ачыла. 1895–1900 дә төрле өяз авылларында 9 *икенче класслы мәктәпләр* эшли. 1906 да *Казан чиркәү-укытучылар мәктәбе* эшли башлый. Һөнәри белем бирү челтәре үсеш ала: 1818 дә *Казан земство фельдшерлык мәктәбе*, 1863 тә *Казан җир эшләре училищесе*, 1891 дә Минзәләдә а.х. мәктәбе, 1897 дә *Казан сәнгать училищесе* булдырыла. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Чистайда һөнәр уч-щесе, Алабугада һөнәр мәктәбе, Буа, Бөгелмә, Зөя, Лаеш, Мамадышта түбәнге һөнәр мәктәпләре, авылларда якынча 20 һөнәри укыту остаханәсе ачыла.

1905–07 елгы рев-ция мәгариф өлкәсендә иҗтимагый һәм шәхси башлангычларның активлашуына китерә: дәүләтнеке булмаган беренче югары уку йорты — *Казан югары хатын-кызлар курслары* (1906), Чистайда (1908), Тәтештә (1912) ир балалар гимназияләре, Казанда (4 нче, 1910), Тәтештә (1906), Мамадышта (1910), Буа, Лаеш, Зөядә (барысы да 1911 дә), Спаста (1913) кыз балалар гимназияләре, Казанда 7 хосусый гимназия ачыла. Земство һәм шәһәр җирле үзидарә органнарының уку йортлары челтәре тиз үсә, алар тарафыннан 30 дан артык *рус-татар училищеләре оештырыла*. 20 йөз башында күпчелек татар мәктәпләре һәм мәдрәсәләр яңа ысул б-н укытуга күчә, урта һәм

югары уку йортларында укучы татарлар саны кискен арта, Казан ун-тында 1906–17 дә татар һәм башкортлардан якынча 100 студент укый. 1914 кә Татарстан терр-ясендә 1 меңнән артык земство, 400 дән артык чиркәү-приход һәм якынча 50 шәһәр башлангыч мәктәбе эшли, балаларның 50% тан артыгы башлангыч мәктәпкә җәлеп ителә. Земстволар тарафыннан гомуми башлангыч белем бирү программасы гамәлгә ашырыла башлый, 1912 дән авылларда тулы булмаган урта уку йортлары — *югары башлангыч училищеләр* ачыла.

Совет хакимияте урнашканнан һәм ТАССР игълан ителгәннән соң, респ-када *культура рев-циясе* җәелдерелә; халык мәгарифе системасы тамырдан үзгәрә: гимназия һәм реаль уч-щеләр бердәм урта мәктәп итеп үзгәртелә, тиз арада яңа югары уку йортлары ачыла. Урта махсус уку йортлары (сәнәгать, җир эшкәртү, коммерция уч-щеләре) берләштерелә һәм Казан политехник ин-ты итеп үзгәртелә (1919), 1922 дә аңардан а.х. һәм урманчылык ин-ты аерылып чыга (к. *Казан аграр университеты*). 1930 да Казан укытучылар ин-ты җирлегендә пед. ин-ты булдырыла (к. *Казан педагогика университеты*). 1919 дан башлап эшче-крәстиян яшьләрен югары уку йортына әзерләү өчен *эшчеләр факультетлары* ачыла башлый.

Гражданнар сугышы һәм 1921–22 елгы ачлык чорында мәгарифне финанслау шактый кими, башлангыч мәктәпләр челтәре кыскара, шуңа күрә 1929 га кадәр авылларда балаларны мәчетләрдә укыту рөхсәт ителә. Халыкның уку-язу дәрәҗәсен күтәрүдә *наданлыкны бетерү* кампаниясе зур роль уйный. Халыкның мәдәнияте һәм мәгариф дәрәҗәсе күтәрелүгә илдә 1933/34 уку елында гомуми башлангыч белем бирүне кертү йогынты ясый. Урта мәктәпләр челтәре дә тиз үсә, укытучы кадрлар әзерләнә, яңа дәреслекләр языла, 1936/37 уку елында шәһәрләрдә җидееллык белем мәҗбүри итеп кертелә.

Халык хуҗалыгын индустрияләштерү һәм а.х.н күмәкләштерү квалификацияле белгечләргә зур ихтыяҗ тудыра, шуңа күрә 1930 еллар башыннан респ-када күп санда фабрика-завод укыту курслары, 17 урта махсус техник һәм 6 а.х. юнәлешендәге уку йорты булдырыла. Химия-технол. ин-ты (хәзер *Казан технология университеты*), авиация ин-ты (*Казан техник университеты*), коммуналь төзелеш ин-ты (*Казан архитектура-төзелеш университеты*), медицина ин-ты (*Казан медицина университеты*), *Казан финанс-икътисад институты* ачыла. 1920–30 елларда беренче тапкыр татар телендә гомуми һәм пед. белем бирүнең бербөтен дәүләт системасы булдырыла: ана телен һәм әдәбиятын өйрәнү, рус телен заманча методика буенча өйрәнү программалары һәм укыту ярдәмлекләре, табигыять һәм гуманитар фәннәр буенча тәрҗемә дәреслекләрнең тулы комплекты әзерләнә. Милли мәктәп булдыруда галимнәр — тел белгечләре һәм педагоглар Н.К.Мөхетдинов, М.Х.Корбангалиев, М.Ә.Фазлуллин, Г.Ш.Шәрәф зур өлеш кертәләр. Татар телендә алфавит алышыну (10 ел эчендә ике тапкыр) ТАССРда һәм аннан читтә милли мәктәп үсешенә җитди кыенлык тудыра.

Респ-ка мәгариф системасы Бөек Ватан сугышы елларында пед. кадрлар б-н, ш.у. матди-техник базаны, мәктәпләрне дәреслекләр һәм уку-укыту әсбаплары б-н тәэмин итүдә зур кыенлыклар кичерә. Бу чорда Казан югары уку йортлары җирлегендә эвакуацияләнеп килгән Ленинград химия-технол. һәм финанс-икътисад ин-ты, Харьков авиация ин-ты эшли.

СССРда сугыштан соң халык хуҗалыгын торгызу чорының ахырында (1950 еллар уртасы) мәдәният өлкәсендә иң мөһим бурычларның берсе хәл ителә: гомуми җидееллык (1955/56 уку елы) һәм сигезьеллык (1959/60 уку елы) белем бирүгә күчү гамәлгә ашырыла. Халык мәгарифен квалификацияле пед. кадрлар б-н тәэмин итү буенча зур эш башкарыла, 1955–60 елларда 550 яңа мәктәп бинасы төзелә. 1950–70 елларда гомуми белем бирү системасын кайгырту б-н бергә партия һәм дәүләт органнары халыкның мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләренә ихтыяҗын канәгатьләндерүгә зур игътибар бирә. Бу елларда һөнәри-техник уку йортлары челтәрен булдыру халык мәгарифе системасы үсешендә мөһим юнәлешләрнең берсе була. 1970–80 елларда шундый 100 уч-ще ачыла. Әлеге чорда ТАССРда югары мәктәп яңа баскычка күтәрелә. Югары уку йортларында студентлар саны сизелерлек арта, белгечлекләр исемлеге киңәя. Авиация, химия-технол., төзүче инженерлар ин-тлары тармак ин-тларыннан политехник ин-тлар итеп үзгәртелә (халык хуҗалыгының төрле тармаклары өчен белгечләр әзерлиләр). Югары уку йортлары респ-каның башка шәһәрләрендә дә ачыла (к. *Алабуга педагогика университеты, Кама политехник институты, Әлмәт нефть институты, Түбән Кама химия-технология институты*). 1970 елларда мәктәп яшендәге балаларны гомуми мәҗбүри урта белем алуга күчерү гамәлгә ашырыла.

КПССның яңа тарихи бергәлек — совет халкын формалаштыру курсы нигезендә 1950 еллар ахырыннан татар телендә һәм рус булмаган башка халыклар телендә укытуны бетерү сәясәте уздырыла, югары уку йортларында, урта махсус һәм һөнәри уку йортларында татар телендә укыту туктатыла, шәһәрләрдәге һәм район үзәкләрендәге барлык милли мәктәпләр рус телендә укытуга күчә, рус мәктәпләрендә укучы татар балаларын ана телен өйрәтү кыскартыла. 1980 еллар башында Казанда нибары 1 татар мәктәбе кала.

1980 еллар ахырында социаль-икътисади мөнәсәбәтләрне үзгәртеп кору башлану һәм 1990 елларның 1 нче яртысында килеп туган авыр икътисади вазгыять мәктәпләр һәм һөнәри-техник уч-щеләр челтәренең кыскаруына китерә. Ведомстволар карамагындагы мәктәпкәчә яшьтәге йөзләрчә балалар учреждениеләре ябыла, аларның бинаалары башка максатларда файдаланыла башлый. 1990 елларда респ-када милли мәдәниятне яңадан торгызу, милли мәктәпләр эшен яңарту, балаларның ана телен өйрәнүен оештыру буенча эшчәнлек җәелдерелә. 1990–2000 елларда Татарстан шәһәрләрендә татар гимназияләре челтәре булдырыла, күп мәктәпләрдә татар класслары эшли башлый, гомуми белем бирү мәктәпләре программаларына татар телен өйрәтү кертелә. Махсуслаштырылган мәктәпләр, гимназия, лицейларның саны сизелерлек арта, дәүләтнеке булмаган мәктәпләр барлыкка килә. Авиация, химия-технол., энергетика ин-тлары киң профильле югары уку йортлары — университетлар итеп үзгәртелә: Казан техник ун-ты, Казан технол. ун-ты, *Казан энергетика университеты*. 1990 елларда ТР бюджетыннан финанслана торган югары уку йортлары булдырыла: *Татар гуманитар институты* һәм *Татар-Америка региональ институты*. 2005 тә алар Казан пед. ун-ты б-н *Татар гуманитар-педагогика университетына* берләштерелә. Мөстәкыйль югары уку йортлары һәм Казан югары уку йортларының Әлмәт, Алабуга, Бөгелмә, Чаллы, Чистай шәһәрләрендәге ф-лары бу шәһәрләрдә яшәүчеләрнең югары белемгә төп ихтыяҗларын тәэмин итә. Шактый санда дәүләтнеке булмаган югары уку йортлары булдырыла, кайберләре эре мәгариф үзәкләренә әверелә: *Икътисад, идарә итү һәм хокук институты, Казан социаль-юридик институты, «ТИСБИ» идарә университеты, Чаллы идарә итү институты, Түбән Кама муниципаль институты.*

Милли-тикшеренү ун-тлары статусы Казан техник ун-тына (2010) һәм Казан технология ун-тына (2010) бирелә. 2010 да Казан ун-ты Казан (Идел буе) федераль ун-ты итеп үзгәртелә, аның составына Татар гуманитар-пед. ун-ты, Казан финанс-икътисад ин-ты, ТР Президенты каршында дәүләт хезмәте ин-ты, Алабуга пед. ин-ты керә. 2013 тә Татарстанда якынча 1958 мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениесе (94 мең бала), 1488 гомуми белем бирү мәктәбе (якынча 375 мең укучы), 16 дәүләти югары уку йорты һәм 11 дәүләтнеке булмаган югары уку йорты, югары уку йортларының 44 ф-лы (170 мең студент), 103 урта һөнәри уку йорты (якынча 66,8 мең укучы) эшли.

**Фән.** Төбәктә беренче фәнни хезмәтләр Идел буе Болгар дәүләтендә дөнья күрә. Ягъкуб бине Ногман «Тәварихы Болгария» («Болгар тарихы») хезмәтен яза, Таҗеддин бине Юныс әл-Болгариның тыйб гыйлеменә караган «әт-Тирьяк әл-Кәбир» («Зур тирьяк») хезмәте сакланган; кайбер дин һәм фәлсәфә галимнәренең исемнәре (Хуҗа Әхмәд әл-Болгари, Борһанетдин Ибраһим бине Йосыф әл-Болгари, Сөләйман бине Дауд әс-Саксини әс-Сувари һ.б.) билгеле. 14 йөз башыннан, монгол яуларыннан соң, Алтын Урда башкаласы Сарай әл-Җәдид шәһәре Идел буеның мәдәни һәм фәнни үзәгенә әверелә, ә аның күренекле зыялыларының шактый өлешен Идел буе Болгар дәүләте галимнәре тәшкил итә. Дин гыйлеме, математика, география, медицина, астрономия һ.б. фәннәр элеккечә үк үсеш кичерә. Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» (1394) поэмасында, Коперниктан шактый үк элек, Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүе турындагы фикер әйтелә. Казан ханлы-









1. Казан университеты. Төп бина; 2. Казан университетының Л.Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара багланышлар институты; 3. Казан техник университеты. 5 нче уку бинасы; 4. «ТИСБИ» идарә университеты. Төп бина; 5. Казан энергетика университеты; 6. Түбән Кама химия-технология институты. Төп бина.

гында фәнни эшләр алып барылу хакында ышанычлы мәгълүматлар сакланмаган.

Казан губернасында фәннәр үсеше 18 йөзнең 1 нче яртысында, Идел-Урал төбәге Петербург ФАнең системалы фәнни тикшеренүләр планына кертелгәннән соң башлана. 1730 еллардагы (катнашучылар — Г.Ф.Миллер, С.М.Гмелин һ.б.) һәм 1760 еллардагы (И.И.Лепёхин, П.С.Паллас, И.И.Георги һ.б.) *академия экспедицияләре* нәтиҗәсендә Казан төбәге тарихына, этнографиясе, мәдәниятенә караган хезмәтләр басыла: П.И.Рычков, «Казанның борынгы һәм урта чорлар тарихы тәҗрибәсе» («Опыт Казанской истории древних и средних времён», 1767; Г.Ф.Миллер, «Казан губернасында яшәүче мәҗүси халыкларны, ягъни чирмеш, чуаш һәм вотякларны тасвирлау» («Описание живущих в Казанской губернии языческих народов, яко то черемис, чуваш и вотяков», 1791) һ.б.

19 йөздә — 20 йөз башында Казанда фәнни тикшеренүләр, башлыча, югары уку йортларында, бигрәк тә Казан ун-тында алып барыла. Университет галимнәре тарафыннан дөньякүләм әһәмияткә ия булган ачышлар ясала һәм фәнни теорияләр бәян ителә: математикада — *Лобачевский геометриясе*, Н.А.Васильевның нәклассик мантыйк системасы, химиядә — *Зинин реакциясе*, К.К.Клаусның *рутений* элементын ачуы, А.М.Бутлеровның *химик төзелеш теориясе*, *Марковников кагыйдәсе, Попов кагыйдәсе, Зайцев кагыйдәсе*, лингвистикада — И.А.*Бодуэн де Куртенэның* фонемалар һәм фонетик алмашынып килүләр теориясе һ.б. Университетта астрономия, геология, геоморфология, геометрия, лингвистика, медицина һ.б. фәнни мәктәпләр барлыкка килә (к. *Казан фәнни мәктәпләре*). 19 йөзнең 1 нче яртысында Казан ун-тының *Шәрекъ бүлеге* Россиядә Шәрекъне өйрәнү буенча әйдәп баручы үзәк була.

Казан руханилар академиясендә гуманитар фәннәрнең киң даирәсе буенча тикшеренүләр гамәлгә ашырыла, биредә рус чиркәве тарихы (П.В.Знаменский), чиркәү хокукы (И.С.Бердников), фәлсәфи антропология (В.И.Несмелов) һ.б. мәктәпләр формалаша. Казан вет. ин-тында фәнни һәм гамәли тикшеренүләр алып барыла (к. *Казан ветеринария фәнни мәктәбе*). Казанда күп кенә фәнни юнәлешләргә нигез салган күренекле галимнәр: математик А.В.Васильев, астроном М.А.Ковальский, механик А.Ф. Попов, химиклар А.М.Зайцев, Ф.М.Флавицкий, медиклар Е.В.Адамюк, В.М.Бехтерев, Н.О.Ковалевский, П.Ф.Лесгафт, биологлар Н.П.Вагнер, А.О.Ковалевский, тарихчылар Н.П.Загоскин, Д.А.Корсаков, М.М.Хвостов, филологлар В.А.Богородицкий, В.И.Григорович һ.б. эшли. *Казан икътисадчылар җәмгыяте,* Казан табибләр җәмгыяте, *Табигыятьчеләр җәмгыяте, Казан физика-математика җәмгыяте* уңышлы эшләп килә, бу җәмгыятьләрдә галимнәр янәшәсендә гамәли белгечләр, фәннәрне сөючеләр дә фәнни эш б-н шөгыльләнәләр.

18 йөзнең 2 нче яртысыннан Казан татар телен, тарих, этнография, фольклорны өйрәнү үзәгенә әверелә. 1778 дә С.Хәлфинның беренче татар теле дәреслеге басылып чыга. 19 йөзнең 1 нче яртысыннан татар халкын өйрәнү гыйлеме Казан ун-тының Шәрекъ бүлеге галимнәре Х.Д.Френ, И.Н.Березин, К.Ф.Фукс һ.б.ның хезмәтләрендә үстерелә. Казан руханилар академиясендә, татарлар арасында актив миссионерлык эшенең үтемлерәк алымнарын булдыру максатыннан, ислам динен, татар телен киңрәк күләмдә өйрәнү алып барыла (Н.И.Ильминский, Е.А.Малов, М.А.Машанов һ.б.). 19 йөзнең 2 нче яртысында татар телен, тарихын һәм этнографиясен өйрәнү эшенә татар галимнәре — Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Х.Әмирханов, Х.Габәши, 20 йөз башыннан Г.Әхмәров һәм Һ.М.Атласов һ.б. алына. Казан ун-тының Шәрекъ бүлеген С.-Петербург ун-тына күчергәннән соң, татар халкын өйрәнү гыйлеменә караган хезмәтләрне *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* нәшер итә. Гражданнар сугышы елларында, икътисади җимереклек һәм профессорларның массакүләм эмиграциясе сәбәпле, күп кенә фәнни тикшеренүләр тукталып кала. Шуннан соңгы елларда СССРда фәнне үстерү дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлеше дип билгеләнә, нәтиҗәдә, фәнне финанслау арта, махсус фәнни учреждениеләр булдырыла, тикшеренү һәм проектлау эшчәнлегенең программалары эшләнә.

Элек эшләп килгән һәм яңа оештырылган югары уку йортлары (Казанда медицина, авиация, химия-технол. ин-тлары) төп фәнни-тикшеренү үзәкләре булып кала бирә.

Бу елларда *Казан метеорология фәнни мәктәбе, Казан геоморфология фәнни мәктәбе*, Н.Г.*Четаевның* механикада *хәрәкәт тотрыклылыгы теориясе* мәктәбе, Н.Г.Чеботарёвның — алгебра, Н.Н.Парфентьевның — матем. анализ, А.Е.Арбузовның — *фосфорорганик кушылмалар* химиясе, В.А.Энгельгардт һәм А.А.Баевның молекуляр биология мәктәпләре оеша. Гуманитар фәннәр, бигрәк тә татар халкын өйрәнү гыйлеме өлкәсендә тикшеренүләр үсеш ала, биредә үзәк урыннарны *Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография институты, Шәрекъ академиясе, Татар мәдәнияте йорты* били. Яңа фәнни учреждениеләр: Гыйльми үзәк, Татар икътисад ин-ты, ТАССР ХКС каршында Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү ин-ты (к. *Тел, әдәбият һәм тарих институты*) оештырыла. Тарих, этнография, археология, лингвистикага, әдәбият белеменә һәм башка мәсь-

әләләргә караган зур күләмле тикшеренүләр башлана, аларда Җ.Вәлиди, Г.Гобәйдуллин, Г.Ибраһимов, Н.Н.Фирсов, В.А.Богородицкий, В.Ф.Смолин, Г.М.Рәхим, Г.Ш.Шәрәф, Г.Ә.Нигъмәти, Г.Х.Алпаров, М.Ә.Фазлуллин, М.Г.Худяков, Н.Ф.Калинин, Н.И.Воробьёв һ.б. галимнәр зур роль уйный. Фәнни хезмәткәрләр саны арта (1926 да — 650, 1940 та — 1300 дән артык кеше). Ләкин КПССның идеологик диктаты фәнни тикшеренүләр үсешенә тискәре йогынты ясый; 1920 еллар ахырында — 1930 еллар башында төбәкне өйрәнү эшләре туктатыла, Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте һәм Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте бөтенләй ябыла; 1937–38 дә 50 дән артык галим сәяси репрессияләргә дучар була.

Бөек Ватан сугышы елларында Казанга СССР ФА фәнни учреждениеләренең бер өлеше эвакуацияләнә, 1884 фәнни хезмәткәр, ш.и. СССР ФАнең 93 академигы һәм мөхбир әгъзалары: И.П.Бардин, С.И.Вавилов, Б.Д.Греков, Н.Д.Зелинский, А.Ф.Иоффе, П.Л.Капица, М.В.Келдыш, В.А.Котельников, А.Н.Крылов, Л.Д.Ландау, С.С.Намёткин, А.Н.Несмеянов, С.П.Обнорский, Л.А.Орбели, А.Е.Порай-Кошиц, Н.Н.Семёнов, С.Л.Соболев, Е.В.Тарле, А.Е.Ферсман, Я.И.Френкель, Е.А.Чудаков, О.Ю.Шмидт һ.б. килә. Күренекле галимнәр б-н бергәләп эшләү җирле фәнни кадрларның иҗади үсешенә этәргеч бирә һәм фундаменталь фәннәр өлкәсендәге тикшеренүләрне активлаштыра. Казанда өр-яңа коралланy системалары, ш.и. атом коралы (И.В.Курчатов, А.П.Александров) уйлап табыла. Хәрби самолётлар һәм реактив двигательләрнең яңа типларын булдыруда В.П.Глушко, С.П.Королёв, В.М.Петляков, А.Н.Туполев һ.б. хезмәт куя. 1944 тә Е.К.Завойский *электрон парамагнетик резонанс* күренешен ача; аның ачышы Казан физиклары өчен төп тикшеренү юнәлешләренең берсенә әверелә (к. *Казан радиоспектроскопия фәнни мәктәбе*). 1945 тә СССР ФАнең Казан ф-лы оештырыла (РФА КГҮ; к. *Россия Фәннәр академиясенең Казан гыйльми үзәге*), аның составына яңа төзелгән Химия ин-ты (к. *Органик һәм физик химия институты*), Биология ин-ты (Казан биохимия һәм биофизика институты), Физика-техника ин-ты (*Казан физика-техника институты*), Геология ин-ты (*ЦНИИГеолнеруд*), *Тел, әдәбият һәм тарих институты* керә.

Казанның куәтле фәнни потенциалы 1950 елларның 2 яртысында гамәли фәнни тикшеренүләрнең тиз үсеп китүенә сәбәпче була. 1950–70 елларда респ-каның башкаласында һәм башка шәһәрләрендә күп кенә тармак фәнни-тикшеренү ин-тлары ачыла, һәм алар фундаменталь фәннәрне үстерүгә дә, сәнәгать һәм а.х.ның мөһим бурычларын хәл итүгә дә зур өлеш кертә. Шуннан соңгы унъеллыкларда ведомстволарга караган фәнни-тикшеренү ин-тлары, ФҖБ, проектлау-конструкторлык бюролары һ.б фәнни-тикшеренү оешмалары булдырыла, һәм 1980 еллар ахырына аларның саны 104 кә җитә. Гамәли хезмәт б-н югары уку йортлары һәм акад. институтларның хезмәткәрләре дә актив шөгыльләнә.

Химия фәнендәге: *фосфорорганик кушылмалар* (А.Е. һәм Б.А. Арбузовлар, А.Н.Пудовик), *мышьякорганик кушылмалар* (Г.Х.Камай), *элементорганик кушылмалар* (О.Г.Синяшин, И.А.Нуретдинов, Р.А.Черкасов), *югары молекуляр кушылмалар* (П.А.Кирпичников, Б.Е.Иванов) өлкәсенә, органик һәм супрамолекуляр физик химиягә (А.И.Коновалов, И.С.Антипин), *координацион химиягә* (А.И.Троицкая, Н.С.Әхмәтов), *нәорганик химиягә* (Л.Г.Берг, А.А.Попель), *электрохимиягә* (Г.С.Воздвиженский, А.Ф.Богоявленский),



Россия Фәннәр академиясенең Казан гыйльми үзәге.

*аналитик химиягә* (В.Ф.Торопова, Г.К.Будников), махсус химиягә (Н.А.Холево, Ф.П.Мадякин, В.Я.Базотов, И.Я.Фәләхов), *композицион электрохимик капламнар* булдыруга (Р.С.Сәйфуллин), *полиэлектролитлар* һәм дисперс системаларының физик химиясенә (В.П.Барабанов), *химиядә физик тикшеренүләр* алымнарына (А.Н.Верещагин, Ю.Ю.Сәмитов), химия технологиясенә (Т.Г.Әхмәтов, А.Г.Лиакумович, Б.Р.Серебряков), нефть химиясе һәм аның җитештерү технологияләренә (А.Г.Лиакумович, И.Н.Дияров, Ә.М.Мазһаров) караган зур казанышлар киң танылу ала. 2000 елларда супрамолекуляр химия һәм нанокисәкчекләр өлкәсендә фундаменталь тикшеренүләр уздырыла.

Механика өлкәсендәге тикшеренүләр (Х.М.Мөштәри, К.З.Галимов, М.Т.Нужин, Г.Г.Тумашев, Һ.С.Салихов, С.Г.Нужин, М.С.Корнишин, Г.В.Каменков, В.Г.Павлов, В.М.Матросов, Т.К.Сиражетдинов, В.Н.Скимель-Оше, Ю.Г.Одинцов, А.В.Степанов, М.Б.Вахитов, Ю.Г.Коноплёв, И.Г.Терегулов, М.Ә.Илһамов, А.В.Кузнецов, О.М.Киселёв), очкыч аппарат двигательләренең физик-техник проблемаларын хәл итү (А.В.Болгарский, Г.С.Жирицкий, В.Е.Алемасов, А.В.Талантов) зур гамәли әһәмияткә ия була.

Гамәли юнәлештәге матем. тикшеренүләр (Р.Г.Бохараев, А.В.Сульдин, Н.К.Замов, А.Д.Ляшко, Я.И.Заботин, Т.К.Сиражетдинов, Ю.В.Кожевников, Г.Л.Дегтярёв), функциональ анализ (А.Н.Шерстнев, Б.Г.Габделхәев, Л.И.Чибрикова һ.б.) алга китә. Математика, механика һәм машиналар төзелеше өлкәсендә инновацион тикшеренүләр уздырыла, аларның нәтиҗәләре «КАМАЗ», «Россия вертолётлары» ААҖләрендә җитештерүдә файдаланыла. Төп нәтиҗәләр экология таләпләрен үтәп, КАМАЗ автомобильләре өчен ягулыкның альтернатив төрләрен кулланучы двигательләр эшләү проектын гамәлгә ашыруга карый. Шарнирсыз калаклы вертолёт очышы динамикасын имитацияләп модельләү алымы эшләнә. Очучысыз очкычларның тәҗрибә үрнәкләрен эшләү һәм җитештерү сизелерлек казаныш булып тора. Планерның агрегатларын полимер композицион материаллардан эшләү буенча проектлар төзелә. Энергия җайланмалары эчендәге яну процесслары, эчке янулы двигатель цилиндрындагы эш процесслары математик җәһәттә модельләштерелә.

Шулай ук физика өлкәсендәге, бигрәк тә электрон парамагнетик һәм төш-магнит резонансларын өйрәнүгә караган хезмәтләр (С.А.Альтшулер, Б.М.Козырев, К.Ә.Вәлиев, Л.К.Әминов, Б.И.Кочелаев, М.М.Зарипов, Ю.Я.Шамонин, В.Н.Ястребов, М.А.Теплов, Н.С.Гарифҗанов, Э.Г.Харахашьян, И.Г.Гарифуллин, Һ.С.Салихов, В.М.Винокуров, Ә.В.Ильясов, А.И.Маклаков, В.Д.Скирда, Н.А.Мальцев, В.Д.Федотов, А.В.Анисимов) дөньякүләм танылу таба. Казан галимнәренең радиоспектроскопия өлкәсендәге тикшеренүләре фәндә яңа юнәлешләр тууга һәм эргәдәш юнәлешләрнең (*акустик парамагнетик резонанс, фотон кайтавазы*, Мёссбауэр радиоспектроскопиясе) үсүенә ярдәм итә. 2000 елларда физика өлкәсендә перспективалы җир өсте системаларының мәгълүмат б-н тәэмин ителеш дәрәҗәсен күтәрү өчен яңа физик принциплар, ш.у. оптик нурланышның фәзаи кысылышының яңа принциплары эшләнә һәм мәсьәләнең нанометрлы диапазонда хәл ителүенә ирешелә, аеруча катлаулы мәгълүматны магнитлы язу һәм саклауның яңа физик принциплары булдырыла. Гамәли тикшеренүләр радио- һәм телекоммуникация системаларының нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелә. Яңа юка сүрүле плазма материалларын синтезлау буенча теоретик һәм эксперименталь мәсьәләләр хәл ителә, шул материалларның оптик сыйфатлары тикшерелә.

Казан астрономнары Галактика структурасын өйрәнү (Ш.Т.Хәбибуллин), йолдызлар астрофизикасы (Д.Я.Мартынов, М.И.Лавров, Н.А.Сәхибуллин) буенча тикшеренүләр алып баралар, Галактикадан читтәге объектларның физикасын өйрәнү буенча халыкара космик проектларда актив катнашалар («Integral», «PZANK» проектлары).

Геологиягә караган тикшеренүләр (Б.П.Кротов, В.А.Чердынцев, Л.М.Миропольский, Е.И.Тихвинская, Р.Х.Мөслимов, Б.М.Йосыпов, У.Г.Дистанов һ.б.) зур фәнни һәм гамәли әһәмияткә ия була, шулар нигезендә 250 нефть чыганагы, ш.и. уникаль Ромашкино чыганагы, ш.у. 1100 дән артык руда булмаган каты файдалы казылмалар чыганаклары ачыла.

Университетта биологиянең күп бүлекләре: генетика (Б.И.Барабанщиков), биохимия (И.А.Тарчевский, В.Г.Винтер), үсемлекләр физиологиясе (А.М.Алексеев, Л.П.Хохлова), кеше һәм хайваннар физиологиясе (А.Ф.Самойлов, И.Г.Вәлидов, Л.Н.Зефиров, В.И.Ала-

тырев), микробиология (М.И.Беляева, И.Б.Лещинская), зоология (Н.А.Ливанов, В.Л.Вагин, А.В.Лукин, А.И.Голубев, Ә.Б.Халидов, В.А.Кузнецов), ботаника (А.Я.Гордягин, В.И.Баранов, М.В.Марков, В.С.Порфирьев, Е.Л.Любарский) буенча тикшеренүләр алып барыла.

Медицина галимнәре әлеге фәннең барлык төп юнәлешләре: анатомия (Э.С.Вәлишин), гистология (Г.И.Забусов, Б.И.Лаврентьев), топографик анатомия (Ә.Х.Дәүләтшин, А.А.Агафонов), физиология (А.Ф.Самойлов, А.В.Кибяков, А.Л.Зефиров, Д.М.Зөбәеров, А.П.Цибульский), акушерлык һәм гинекология (В.С.Груздев, И.Ф.Козлов, П.В.Маненков, Н.Е.Сидоров, А.З.Уразаев), офтальмология (В.Е.Адамюк, А.П.Нестеров, А.Г.Агабабов, М.Б.Вургафт, М.В.Кузнецова), дәвалау (Р.А.Лурия, С.С.Зимницкий, Р.И.Лепская, Л.М.Рахлин, Ә.Г.Терегулов, И.П.Арлеевский), травматология (Л.И.Шулутко, Х.З.Гафаров, А.Л.Гиммельфарб), хирургия (А.В.Вишневский, Ю.А.Ратнер, Б.Г.Герцберг, В.Г.Морозов, И.Г.Салихов), неврология (Я.Ю.Люпелянский, В.П.Веселовский, А.В.Фаворский, И.Н.Дьяконова, А.Ю.Ратнер, Г.А.Иваничев), нур диагностикасы (Д.Е.Гольдштейн, М.Х.Фәйзуллин, М.К.Михайлов), онкология (Ю.А.Ратнер, М.З.Сигал, Р.М.Таҗиев, Ф.Ш.Әхмәтҗанов) һ.б. буенча тикшеренүләр һәм гамәли эшләр алып баралар. Медицина һәм биология өлкәсендә туберкулёзга каршы яңа нәтиҗәле һәм куркынычсыз дару препаратлары, гриппның пандермик вирусы, кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ), Эбола бизгәге вирусы кебек куркыныч инфекцияләргә каршы көрәшнең терапия алымнары эшләнә. Онкология авыруларын башлангыч чорында ачыклауга һәм аларның барлыкка килүенә йогынты ясаучы факторларга аерым игътибар бирелә. Магнит резонансы, импульслы икеләтелгән электрон-электронлы резонанс методологиясен үстерү буенча эшләр алып барыла. Магнит-резонанс томографиясен (МРТ) фәзаи һәм вакыт җәһәтендә яхшырту методикалары эшләнә, бу пациентларны МРТ алымы б-н тикшерү вакытының кыскаруына китерә.

Казан вет. ин-ты (к. *Казан вет. медицинасы академиясе*) һәм *Бөтенроссия вет. ин-ты* (к. *Хайваннарның токсикологик һәм радиацион куркынычсызлыгы Федераль үзәге*) ветеринария һәм зооинженериянең төрле юнәлешләрендә: анатомия (Д.М.Автократов, А.Ф.Климов), патологик анатомия (Г.З.Идрисов), микробиология һәм иммунология (М.В.Рево, Х.Х.Абдуллин), дәвалау (Г.В.Домрачев), вет. хирургиясе (М.Ш.Шәкүров), вет. акушерлыгы (А.П.Студенцов), а.х. терлекләрен тукландыру (Л.П.Зарипова) һ.б. өлкәләрдә зур тикшеренү үзәкләренә әвереләләр.

Галимнәрнең М.И.Мәхмүтов җитәкчелегендәге *проблемалы укыту* теориясенә һәм практикасына караган эшчәнлеге пед. фәнен үстерүдә мөһим роль уйный.

Казан лингвистика фәнни мәктәбе традицияләре үсешкә ирешә, татар лингвистикасы (Г.Х.Алпаров, М.Х.Корбангалиев, М.З.Зәкиев, Д.Г.Тумашева, Л.Т.Мәхмүтова, Һ.В.Йосыпов, Ф.Ә.Ганиев, В.Х.Хаков, Г.Ф.Саттаров, Ф.Г.Гарипова һ.б.), рус теле тарихы (В.М.Марков, Г.А.Николаев) фәнни мәктәпләре барлыкка килә. Татар әдәбият белеме (Г.Кашшаф, М.Х.Гайнуллин, Г.Халит, М.Х.Хәсәнов, И.З.Нуруллин, Х.Г.Госманов, Н.Г.Юзиев, Р.К.Ганиева, А.Г.Әхмәдуллин, Т.Н.Галиуллин, Х.Й.Миңнегулов, Н.Ш.Хисамов, Ф.Г.Галимуллин, Ф.М.Мусин, Д.Ф.Заһидуллина), китап белеме һәм археография (Ә.Г.Кәримуллин, Ш.Ш.Абилов, М.Г.Госманов, М.В.Гайнетдинов, Ф.С.Фасиев, Н.Г.Юзиев, Һ.В.Йосыпов, Р.Ф.Исламов,



Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе.

Җ.С.Миңнуллин, Р.Ф.Мәрдәнов) фәннәре формалаша. Тарих фәнен үстерүгә иҗтимагый фикер (М.И.Абдрахманов, Я.Г.Абдуллин, Р.Г.Әмирханов, Р.М.Әмирханов, А.Н.Юзиев, Р.С.Хәкимов), археология (А.П.Смирнов, Н.Ф.Калинин, А.Х.Халиков, Ә.Г.Мөхәммәдиев, Е.П.Казаков, Ф.Ш.Хуҗин, А.Г.Ситдыйков), татар халкы (Х.Х.Хәсәнов, Ш.Ф.Мөхәммәдъяров, М.Г.Госманов, И.Р.Таһиров, Р.Г.Фәхретдинов, Р.К.Вәлиев, Д.М.Исхаков, М.И.Әхмәтҗанов, И.А.Гыйләҗев, И.Л.Измайлов, Р.Р.Салихов, Р.В.Шәйдуллин, Рафаэль М.Вәлиев), Россия һәм җирле төбәк (Г.Н.Вульфсон, И.П.Ермолаев, С.Х.Алишев, Ю.И.Смыков, А.Л.Литвин, Д.М.Госманова, Ә.Г.Галләмова), антик чор (А.С.Шофман, В.Д.Жигунин) тарихын тикшерүчеләр зур өлеш кертә. РФА КГҮ ин-тларында җылылык энергетикасы (В.Е.Алемасов, Ю.Г.Нәҗмиев һәм аларның шәкертләре), супрамолекуляр кушылмалар химиясе (А.И.Коновалов), элементорганик кушылмалар химиясе (О.Г.Синяшин), биохимия (А.Н.Гречкин), үсемлекләр физиологиясе (А.В.Кобяков, Н.А.Гусев, И.А.Тарчевский), кеше һәм хайваннар физиологиясе (Е.Е.Никольский), химик физика (К.М.Салихов) өлкәсендә илнең әйдәп баручы фәнни мәктәпләренә караган зур фәнни коллективлар формалаша. 1990 елларның 1 нче яртысында, илнең икътисади хәле авыр булу сәбәпле, фәнни тикшеренүләрне финанслау кискен кими һәм бу күп кенә фәнни учреждение лаб-яләренең ябылуына, гамәли тикшеренүләр тематикасының тараюына, фәнни хезмәткәрләр санының кыскаруына китерә. Шундый шартларда 1992 дә ТР ФА төзелә һәм ул фәнни потенциалны саклап калуда, алга таба тикшеренүләр эшчәнлеген үстерүдә мөһим роль уйный. Академиянең 7 бүлекчәсендә тарих, филология, философия, политология, психология, педагогика, сәнгать белеме, хокук белеме, биология, медицина, математика, механика һәм машиналар төзү, физика, энергетика, Җир турындагы фән, химия һәм химия технологияләре буенча әйдәп баручы белгечләр хезмәт куя. ТР ФА Татарстандагы барлык фәнни учреждениеләр һәм югары уку йортларының интеллектуаль потенциалын берләштерә, өстенлекле юнәлешләр буенча 5 еллык дәүләт программаларын эшли. 1994 тә ТР ФАнең *Татар энциклопедиясе институты* төзелә; фундаменталь басма — 6 томлык Татар энциклопедиясе респ-када фәнни тикшеренүләрне, бигрәк тә төрле гыйльми өлкәләргә караган фәннәр белеме һәм историография тикшеренүләрен тагын да үстерү өчен этәргеч булып тора. 1997 дә ТР ФА Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты *Тарих институты* б-н Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тына бүленә. 1990–2016 елларда татар акад. грамматикасының 3 томлыгы, рус һәм татар телләрендә «Татар энциклопедия сүзлеге», «Татар энциклопедиясе»нең рус телендәге барлык 6 томы да нәшер ителү, татар телендәге 1–5 томнары, татар фольклорының 12 томлык җыентыгы, «Татарлар» фундаменталь хезмәте, 7 томлы «Иң борынгы заманнардан алып татарлар тарихы» басылып чыгу Татарстанның фәнни тормышында әһәмиятле вакыйга була.

Нефтьче галимнәр нефтьне, ш.и. авыр, үзле битумлы, сланецлы нефтьне разведкалау, сәнәгый әзерләү, транспортлау һәм чыгаруның өр-яңа технологияләр комплексын һәм техник чараларын, ш.у. атмосферага нефть парларын чыгармый калуның махсус технологиясен эшли һәм гамәлгә кертә; горизонталь бораулауның прогрессив технологиясен эшли; нефть химиясе белгечләре нефтьне һәм нефть продуктларын күкертле катнашмалардан чистартуның яңа технологиясен эшли. Физиклар тарафыннан оригиналь аз магнит кырлы җайланма эшләнә, онкологик авыруларны иртәрәк диагнозлау өчен ТМРлы томография ысулы камилләштерелә.

2015 елда Казанда ТР ФАнең 6 ин-ты һәм 7 үзәге, РФА КГҮнең 4 ин-ты һәм Энергетика проблемаларын тикшерү үзәге (523 фәнни хезмәткәр, ш.и. 99 фән д-ры һәм 327 фән канд-ты), Россия Мәгариф академиясенең Һөнәри белем бирү педагогикасы һәм психологиясе ин-ты, Россия а.х. фәннәре академиясенең Татарстан агрохимия һәм туфрак белеме фәнни-тикшеренү ин-ты, югары уку йортларындагы 10 фәнни-тикшеренү ин-ты, 100 дән артык үзәк һәм лаборатория (ш.и. Казан ун-тында — 3, техник ун-тта — 5 , технол. ун-тта 2 фәнни-тикшеренү ин-ты), ведомстволар һәм акционерлар карамагындагы 18 фәнни-тикшеренү ин-ты һәм 20 дән артык башка тикшеренү учреждениеләре, ш.и. Хайваннарның токсикологик һәм радиацион куркынычсызлыгы Федераль үзәге, Бөтенроссия углеводород чималы ин-ты, Химия продуктлары ин-ты, Бөтенроссия мед. инструментлары фәнни-тикшеренү ин-ты, Гамәли оптика ин-ты, Казан эпидемиология һәм микробиология ин-ты, «Вакууммаш» ФҖБ, Нефть промыселы химиясе ин-ты, Үзәктән куулы һәм роторлы компрессорлар ин-ты, Ка-

зан авиация технологиясе ин-ты, Татарстан нефть машиналары төзү ин-ты, «Татарстан кыры» («Нива Татарстана») ФҖБ (барысы да Казанда), Татарстан нефть институты (Бөгелмә ш.), «Түбәнкаманефтехим» АҖнең фәнни-технол. үзәге (Түбән Кама ш.), Яшел Үзән проектлау-конструкторлык бюросы, «Вектор» конструкторлык-технол. бюросы (Чистай ш.) исәпләнә.

Фәнни учреждениеләрдә һәм югары уку йортларында 8 меңнән артык фәнни һәм 10 мең тирәсе фәнни-пед. хезмәткәр, ш.и. РФАнең 5 академигы һәм 3 мөхбир әгъзасы, Россия Мәгариф академиясенең 2 академигы һәм 2 мөхбир әгъзасы, ТР ФАнең 40 академигы һәм 80 мөхбир әгъзасы, 2 меңнән артык фән д-ры һәм 11 мең тирәсе фән канд. эшли (2014).

**Әдәбият.** Татар әдәбиятының тамырлары халык авыз иҗатына, төрки халыкларның уртак мәдәни фондын тәшкил иткән 6–12 йөзләрдәге гомумтөрки язма әдәби ядкәрләргә (Й.Баласагуни, М.Кашгари, Ә.Йүгнәки, Ә.Ясәви, С.Бакыргани һ.б.) барып тоташа. Урта гасырлардан башлап татар әдәбияты гарәп-мөселман цивилизациясе контекстында үсә. Кол Галинең мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» поэмасы — Идел буе Болгар дәүләте мәдәниятенең олуг ядкәре. Әсәрдә камил кеше, гадел идарәче турындагы хыяллар сәнгатьчә гәүдәләндерелә. Татар әдәбияты үсешендә Алтын Урда дәвере (13–15 йөзләр) мөһим урын алып тора. Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис», Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан», Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки», «Сөһәйл вә Гөлдерсен» кебек гуманистик юнәлештәге әсәрләренә идея-тематика байлыгы, тел һәм стиль матурлыгы хас. *Кыйсса, дастан, газәл, касыйдә, мәдхия, мәрсия, робагый* һ.б. жанрлар актив үсә. Алтын Урда таркалганнан соң, Казан татар мәдәни тормышының үзәгенә әверелә. Казан ханлыгы дәверендә татар әдәбиятының үсеше Мөхәммәдъяр, Өмми Камал һәм Колшәриф исемнәре б-н бәйле. Аларның әсәрләрендә күркәм максатларга, яхшы гамәлләргә мәдхия җырлана, дини-суфичылык карашлары чагыла. 1552 елда Казан ханлыгының яулап алынуы, милли изү, христиан чиркәвенең басымы татар әдәбияты үсешен тоткарлый. Бу дәвер тарихи хроникалар һәм героик хикәяләүләр барлыкка килү б-н характерлана. 17 йөзнең 2 нче яртысыннан башлап, Мәүла Колый, Утыз Имәни, Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Шәмсетдин Зәки, Гали Чокрый һ.б.ның иҗатында татар әдәбиятындагы яңа күтәрелеш билгеләре күренә, әлеге авторларның әсәрләрендә әдәплелек вә инсафлылык өлгесе булырдай образ тудыруга омтылыш ясала, түрәләрнең кимчелекләре тәнкыйтьләнә, Шәрекъ әдәбиятының фольклор башлангычы һәм романтик традицияләре чагыла. Урта гасырлар татар әдәбияты 19 йөзгә кадәр традиционализм билгесе астында үсә. 19 йөзнең 2 нче яртысында татар мәгърифәтчелек әдәбияты формалаша. Бу юнәлештә шигърият өлкәсендә — Г.Кандалый, Акмулла, Я.Емельянов, прозада — М.Акъегетзадә, Р.Фәхретдин, З.Бигиев, Ф.Кәрими, драматургиядә Г.Ильяси, Ф.Халиди иҗатлары әһәмиятле роль уйный.

20 йөз башы — татар әдәбияты тарихында идея-эстетик ориентирлар үзгәрү дәверенә, ә милләтне саклау, аның үсеше һәм камилләшүе проблемалары яңа, дөньяви әдәбиятның төп тенденциясенә әверелә. Моңарчы яшәп килгән жанрлар камилләшә, әдәбият мәйданында яңалары пәйда була, әсәрләрнең тематикасы киңәя, вакыйгаларны сәнгатьчә мавыктыргыч һәм кызыклы итеп тасвирлау төп урын ала, әдәби тәнкыйть әдәбиятның зарури бер өлешенә әверелә. Татар әдәбияты мәгърифәтчелек әдәбиятыннан тәнкыйди реализм һәм романтизмга үсеш юлын тиз уза. Г.Тукай, Ф.Әмирхан, М.Гафури, Дәрдемәнд, Г.Исхакый, Г.Ибраһимов, Г.Камал, Ш.Камал, С.Рәмиев, Ш.Бабич, М.Фәйзи һ.б., Шәрекъ, Көнбатыш Европа һәм рус әдәбиятлары туплаган тәҗрибәне һәм алар ирешкән казанышларны иҗади файдаланып, сәнгатьчә югары сыйфатлы әсәрләр тудыруга ирешәләр.

1917 елдан соң СССР халыклары әдәбиятлары коммунистик идеология кысаларында үсә. Электән калган мәдәни мираска, милли әдәбиятларга кимсетеп карау, 1930 еллардагы репрессияләр, 1941–45 еллардагы Бөек Ватан сугышында югалтулар һ.б. нәтиҗәсендә татар әдәбияты бик күп талантлы иҗат әһелләреннән мәхрүм ителә; язучыларның рухи эзләнүләре мәгълүм идея кысаларына бикләнә, иҗади мөмкинлекләре чикләнә. Әмма шул шартларда да әдәбият үсеше тукталмый. 1920–40 елларда Г.Ибраһимов, Ф.Бурнаш, К.Нәҗми (СССР Дәүләт бүләге, 1951), Һ.Такташ, К.Тинчурин, М.Галәү, А.Шамов, Х.Туфан, Г.Кутуй, М.Җәлил (Ленин бүләге, 1957), А.Алиш, Ф.Кәрим, Н.Исәнбәт һ.б. иҗат итә. Өлкән буын совет язучылары традицияләрен Г.Бәширов (СССР Дәүләт бүләге, 1951), И.Гази, Ә.Фәйзи, Ф.Хөсни, М.Әмир, С.Баттал, Ә.Еники, С.Хәким, Н.Арсланов, Г.Әпсәләмов, Х.Вахит, А.Расих һ.б. дәвам итә. 1960 еллардагы «җепшеклек» дәүләтнең демократияләшүенә өметләр б-н истәлекле. Татар әдәбиятын яңартуда «алтмышынчы еллар буыны» зур роль уйный. Р.Төхфәтуллин, А.Гыйләҗев, Г.Ахунов, Н.Фәттах, Ә.Баян, Г.Афзал, Ш.Галиев, И.Юзеев, Ш.Хөсәенов үз чорларының мөһим иҗтимагый һәм әхлакый мәсьәләләрен күтәреп чыгалар. Әлеге чор татар прозасына лиризм көчәю һәм психологизм тирәнәю хас, бу хикәя жанрының чәчәк атуына китерә (Ә.Еники, И.Гази, Ф.Хөсни). Өлкән буын шагыйрь һәм прозаиклар күпгасырлык милли мәдәният, әдәбият, тарих тәҗрибәсенең социаль-фәлсәфи мәгънәсенә тирәнрәк төшенергә омтылалар (С.Хәким, Х.Туфан, Р.Төхфәтуллин һ.б.). 1970–80 елларда тарихи роман үзгәреш кичерә (Н.Фәттах, М.Хәбибуллин), алгы планга халыкның тарихи хәтере мәсьәләсе калкып чыга. «Авыл прозасы» кысаларында традицион-гуманистик кыйммәтләр өстенлеге раслана (М.Мәһдиев, Х.Сарьян, Г.Бәширов), тәнкыйди башлангыч көчәя (А.Гыйләҗев, Н.Фәттах, Ә.Баян). Поэзиядә «шау-шулы» темалардан һәм публицистикадан чигенү күзәтелә. Форма һәм стильләр өлкәсендәге иҗади эзләнүләр фәлсәфилеккә тартылуда һәм фольклор-мифологик башлангычларга мөрәҗәгать итүдә күзәтелә (И.Юзеев, М.Әгъләмов, Зөлфәт, Р.Фәйзуллин, Роберт Әхмәтҗанов һ.б.).

Гасырлар чигендә татар әдәбиятында милләтнең үзаңын үстерүгә һәм югалган рухи байлыкларны кайтаруга юнәлтелгән яңарыш дулкыны күзәтелә. А.Гыйләҗев, З.Зәйнуллин, Ф.Сафин прозасындагы көчле реализм, тоталитаризмны гаепләү (И.Салахов, Г.Тавлин, Р.Мөхәммәдиев), халыкның ерак тарихын яңадан күздән кичерү (Р.Батулла, М.Хәбибуллин, Ф.Латыйфи, В.Имамов) совет чорының иҗтимагый тарихын мифлардан арындыруга юнәлтелгән. Чор һәм геройның совет әдәбиятына каршы куелган яңа концепциясе барлыкка килә (Т.Галиуллин, З.Хәким, Н.Гыйматдинова). Бер үк вакытта прозада романтик (М.Галиев, М.Вәлиев) һәм сентименталь (Ф.Яруллин) тенденцияләрнең яңарышы, психол. (Ф.Садриев, Ф.Бәйрәмова) һәм интеллектуаль (Р.Сибат, Г.Гыйльманов) тенденцияләрнең көчәюе күзәтелә.

20 йөз ахыры — 21 йөз башы татар поэзиясенә реализм (Р.Харис, Л.Шагыйрьҗан, З.Мансуров), романтизм (И.Юзеев, Г.Р.Гатауллин, Зөлфәт) һ.б. иҗат агымнары хас, чынбарлыкның чагылышы, замандашларның рухи кичерешләре (М.Әгъләмов, К.Сибгатуллин, Х.Әюпов) жанрлар һәм жанр формалары төрлелегенә әверелә. Драматургиядә авторларның архетиплар, мифология, фантастика һәм шартлы формалар куллануга (М.Гыйләҗев, З.Хәким), дөньяның «трагик» моделен һәм хәзерге заманның «абсурд» картинасын булдыруга тартылулары күзәтелә. Т.Миңнуллин пьесаларында милләт яңарышы һәм аны саклау мәсьәләләре күтәрелә.

Төрле елларда Татарстанда рус телле язучылар уңышлы иҗат итәләр. Шагыйрьләр Н.Н.Беляев, Р.Р.Бохараев, И.Кәлимуллин, М.Д.Зарецкий, Л.И.Топчий, Н.П.Алешков, Р.Х.Кожевникова, С.В.Малышева, Л.Р.Газизова, Ф.А.Рәсүлева, прозаиклар Г.А.Паушкин, В.В.Корчагин, С.Б.Радзиевская, Н.Н.Орешина, Р.Г.Кутуй, Б.Г.Вайнер, драматург һәм прозаик Д.Н.Вәлиев һ.б.ның иҗатлары аеруча таныла. Чуаш халык шагыйрьләре А.Е.Алга, П.П.Хузангай, П.В.Афанасьев Татарстанда туып, Татарстанда белем алалар һәм иҗади эшчәнлекләрен башлап җибәрәләр. 20 йөздә татар әдәбияты әсәрләре рус теленә, СССР һәм чит ил халыклары телләренә тәрҗемә ителә. Ш.у.к. *Татар әдәбияты, Әдәби тәнкыйть, Әдәбият белеме, Драматургия, Балалар әдәбияты, Татар поэзиясе, Проза.*

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. К., 1984–2001; Средневековая татарская литература XIII–XVIII вв. К., 1999; История татарской литературы нового времени (XIX — начало XX века). К., 2003.

**Музыкаль культура**. Татар халык муз.-поэтик традициясе, башлыча, ангемитон (ярымтонсыз) пентатоникага нигезләнә, аның лад төзелеше хәзерге вакытка кадәр муз. интонация б-н башкаруның төп системасы булып тора. Элекке чорларда проф. музыка җырчы-шагыйрьләр, сарай җырчылары һәм







1. ТРның С.Сәйдәшев исем. Зур концерт залы ; 2. Татар филармониясенең концерт залы;
3. «Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексы. Барысы да – Казанда.

илгизәр музыкант-башкаручылар — чичәннәр иҗаты б-н үзенчәлекле. Төрки һәм ислам дөньясының мәдәни үзәкләре эстетикасы б-н бәйле муз. культураның проф. тармаклары үсеше 16 йөз уртасында Казан ханлыгы яулану б-н туктала. 16 йөзнең 2 нче яртысында — 19 йөз башында татар халкы яшәешендә килеп туган тарихи шартлар нәтиҗәсендә анкың муз. иҗаты, башлыча, борынгы «озын көй» яисә тарихи яктан соңрак барлыкка килгән «кыска көй» стильләре, ш.у. аларның үзара йогынтысында туган үрнәкләр б-н характерланган фольклор формаларындагы җыр сәнгате сыйфатында яши. Шигъри әсәрләрне (проф. авторларның, ш.у. халык арасыннан чыккан исемнәре билгесез авторларның әсәрләре) көйләп уку, бәет һәм мөнәҗәтләрне җырлап башкару традицияләре саклана, музыка уен кораллары (курай, сорнай, думбра, танбур, сызгычлы кубыз, тимер кубыз, гөслә һ.б.) уйнау үсеш ала. Рус муз. культурасы ш.у. фольклор жанрлары һәм чиркәү җырлары б-н билгеле була. 18 йөздә Казанда проф. хәрби оркестрлар, Европа классик музыкасын башкаручы һәвәскәр музыкантлар барлыкка килә.

19 йөздә Казан мәдәни үзәк буларак көчле үсеш ала һәм музыка сәнгате шәһәрнең иҗтимагый тормышында мөһим урын били. Уку йортларында Европа музыка уен коралларында уйнау дәресләре кертелә; Казан ун-ты, Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-ты, руханилар семинариясе, кызлар гимназияләре муз. агарту үзәкләре булып тора. Чиркәү һәм дөньяви хор сәнгате, салоннарда музыка б-н шөгыльләнү үсеш ала. Концерт-филармония һәм опера антрепризалары актив эшчәнлек алып бара, хосусый музыка мәктәпләре ачыла. Р.А.Гуммерт мәктәбе җирлегендә 1904 елда Казан музыка уч-щесе оештырыла. *Рус музыка җәмгыятенең Казан бүлеге, Казан музыка сөючеләр түгәрәге, Казан нәфис сәнгать сөючеләр җәмгыяте*, Казан халык ун-тлары җәмгыяте муз.-иҗтимагый тормышта сизелерлек роль уйныйлар. Казанда Ф.И.Шаляпин туа, шунда үзенең артистлык эшчәнлеген башлап җибәрә.

20 йөз башында заманча татар муз. культурасы (артистларның гастрольлек эшчәнлеген үз эченә алган концерт һәм театраль чыгышлар, грампластинкалар яздыру, милли көйләр җыентыклары, музыка буенча уку ярдәмлекләре бастырып чыгару) формалаша башлый. Татар милли оркестрлары (ансамбльләре) оеша, Казанның *Шәрекъ клубында* һ.б. шәһәрләрдә халык алдында татар музыкасы концертлары куела башлый. Концерт бирүче беренче татар музыкантлары арасында җырчылар К.М.Мотыйгый, Ф.М.Латыйпов, Г.С.Әлмөхәммәдов, Ф.Гомәрова, скрипкачылар В.З.Апанаев, Г.М.Зайпин, пианист-импровизатор З.Я.Яруллин, гармунчылар Ф.Б.Биккинин, Ф.К.Туишев була. Беренчеләрдән булып язма традицияләргә нигезләнгән татар муз. әсәрләре иҗат иткән С.Х.Габәши актив муз.-агарту эшчәнлеге алып бара.

ТАССР барлыкка килгәннән соң, милли мәдәният үсеше дәүләт сәясәтенең бер юнәлешенә әверелә. Респ-каның муз.-иҗтимагый тормышы активлашуга татар телендә радиотапшырулар (1927), Җыр һәм бию ансамбле (1937; к. *Татарстан Республикасының дәүләт җыр һәм бию ансамбле*) оешу, *Татар филармониясе* (1937), *Татар опера һәм балет театры* (1938), Халык иҗаты йорты (1939; к. *Татарстан Республикасының халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре фәнни-методик үзәге*) ачылу этәргеч бирә. Квалификацияле кадрлар әзерләү өчен, ТАССР хөкүмәте башлангычында Мәскәү консерваториясе каршында *Татар опера студиясе* оеша (1934–38). 1945 тә *Казан консерваториясе* ачыла.



Казанда Р.Нуриев исем. 22 нче Халыкара классик балет фестивале афишасы. 2009.

20 йөздә татар композиторлар мәктәбе формалаша, милли традицияләр б-н бөтендөнья музыка сәнгате казанышлары берлеге аның үзенчәлеген билгели. Заманча татар проф. музыкасына нигез салган композитор — С.Җ.*Сәйдәшев*. Ул иҗат иткән музыка гомуммилли мәгънәгә ия була. Үзе нигез салган татар муз. драма жанрында композитор пентатониканың интонацион фонды б-н тональ-гармонияле системаның табигый берлеген гәүдәләндерә, милли муз. стильне яңа интонацияләр б-н баета, симф. оркестр яңгырашы б-н тембр палитрасын киңәйтә. Аның «Совет Армиясе маршы», «Наёмщик», «Кандыр буе», «Зәңгәр шәл», «Бишбүләк», «Күзләр» спектакльләрендәге вокаль номерлары халык тормышына үтеп керә, татар муз. культурасының классик мирасына әверелә. 1920–30 елларда составында С.Х.Габәши, Г.С.Әлмөхәммәдов һәм В.И.Виноградов булган авторлар коллективы тарафыннан беренче «Сания» (1925) һәм «Эшче» (1930) татар опералары иҗат ителә. 1930 да М.Ә.Музаффаров, Н.Г.Җиһанов, Ф.З.Яруллин, Җ.Х.Фәйзи, З.В.Хәбибуллин, А.С.Ключарёв кебек мәшһүр татар композиторлары плеядасының актив иҗат эшчәнлеге башлана. Аларның иҗатлары татар музыкасын СССРның милли композиторлар мәктәпләре ирешкән аеруча истә калырлык казанышлары дәрәҗәсенә күтәрә. 20 йөзнең 2 нче яртысында татар композиторлар мәктәбе даими рәвештә яңа исемнәр б-н тулылану хисабына көчле үсеш ала. 1950 елларда — Ә.З.Бакиров, Х.В.Вәлиуллин, М.Г.Латыйпов, А.З.Монасыйпов, И.Г.Шәмсетдинов, Р.М.Яхин, 1960 елларда — Ф.Ә.Әхмәтов, Р.Н.Белялов, Р.Г.Гобәйдуллин, Р.Ә.Еникиев, Б.Г.Мөлеков, И.Д.Якупов, М.З.Яруллин, 1970 елларда — Р.Ф.Абдуллин, Л.М.Батыр-Болгари, Р.И.Еникиева, Ш.Х.Тимербулатов, Л.Ә.Хәйретдинова, Ә.Җ.Шәрәфиев, М.И.Шәмсетдинова, Ш.К.Шәрифуллин, 1980 елларда Р.З.Ахиярова, Р.Ф.Кәлимуллин үзләренең проф. эшчәнлекләрен башлап җибәрәләр. Бөтен дөньяга танылган композитор С.Ә.Гобәйдуллина Чистайда туа һәм Казанда проф. белем ала. Татар милли музыкасының «алтын фонды»на хәзерге вакытта музыка сәнгатенең барлык жанрлары да керә. Респ-када композиторлык иҗаты үсеше татар интонацион материалында гына муз. әсәрләр иҗат итү б-н чикләнми: муз. башкаручылар репертуарында А.С.Леман, А.Б.Луппов, Л.З.Лю-

бовский, Б.Н.Трубинның муз. әсәрләре дә урын ала. Татарстан композиторларының әсәрләре Россия һәм чит илләрдә башкарыла, халыкара конкурсларда бүләкләргә ия була. Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә Р.Харис либреттоларына куелган «Шагыйрь мәхәббәте» (Р.Ахиярова, 2006), «Кара пулат» (Э.Низамов, 2015) оперлары, «Алтын Урда» (Р.Ахиярова, 2013) балеты респ-каның мәдәни тормышында сизелерлек вакыйга буларак кабул ителә.

Татарстанда Европа, Россия һәм татар милли проф. башкару традицияләрен үстерүче муз.-башкару мәктәпләре үсеш ала. Респ-каның концерт тормышына дирижёрлар Н.Г.Рахлин, Ф.Ш.Мансуров, Р.С.Салаватов, А.И.Шутиков зур өлеш кертәләр. Муз. театрны торгызуда опера башкаручылар З.Г.Байрашева, М.З.Булатова, А.С.Измайлова, Г.М.Кайбицкая, М.М.Рахманкулова, У.Г.Әлмиев, Н.К.Даутов, Ф.Х.Насретдинов, Р.Г.Билалова, Г.И.Сәйфуллина, З.Г.Хисмәтуллина, В.Г.Шәрипова, А.З.Аббасов, З.Д.Сөнгатуллина, В.Ә.Ганиева, Х.А.Бигичев, Г.Т.Ластовка, Р.Ә.Сәхәбиев мөһим роль уйныйлар. Башкаручы-солистлар Р.К.Абдуллин (орган), Р.Ю.Абязов (скрипка), Ш.С.Әмиров (балалайка), гастрольләрдә йөрүче яшь музыкантлар М.В.Казаков (вокал), Е.В.Михайлов, Р.Г.Урасин (фортепиано) һ.б. халыкара танылу алалар. *Татар опера һәм балет театры, Татарстан Республикасының дәүләт симфоник оркестры, Татарстан Республикасының дәүләт халык музыка уен кораллары оркестры, Татарстан республикасының дәүләт җыр һәм бию ансамбле,* «La Primavera» камера оркестры (Казан, сәнгать җитәкчесе Р.Ю.Абязов), «Провинция» камера оркестры (Чаллы ш., сәнгать җитәкчесе И.М.Лерман), *Татарстан Республикасының дәүләт фольклор музыкасы ансамбле* (Казан, сәнгать җитәкчесе А.Ф.Фәйзрахманов), *Татарстан Республикасының дәүләт кыллы квартеты* ТРның әйдәп баручы иҗат коллективлары булып торалар. ТР музыка сәнгатендә акад. юнәлеш б-н беррәттән җыр иҗаты һәм традицион башкару да (С.Г.Садыйкова иҗаты — моның ачык мисалы) зур үсеш ала. Ш.Х.Мәҗитов, З.Х.Гыйбадуллин, М.А.Макаров, Ф.Г.Әхмәдиев һ.б. үзешчән композиторларның җырлары да башкарыла. Җыр сәнгате осталары арасында Г.Н.Сөләйманова, Р.В.Ваһапов, З.Җ.Басыйрова, Ә.А.Авзалова, И.Г.Шакиров, Г.М.Рәхимкулов, Г.Г.Ильясов, Р.З.Ильясов, Ш.С.Әхмәтҗанов, Э.Г.Җәләлетдинов, З.К.Сәхәбиева һ.б. киң таныла. Гармуннарда һәм курайда уйнау үсеш ала; 20 йөз ахырында вакытлыча өзелеп торган борынгы музыка уен коралларында уйнап ялгыз һәм ансамбль б-н җырлап концертлар кую традицияләре яңадан торгызыла башлый. Хәзерге татар мәдәниятендә эстрада-музыка сәнгате зур урын били. Җырчылар Р.И.Ибраһимов, А.Н.Әсәдуллин бөтен Россиягә танылалар. Татар эстрада җырларында хәзерге киң катлау музыканың төрле стиль юнәлешләре чагылыш таба, соңгы елларда аның инфраструктурасы (FM ешлыктагы радиостанцияләр, студиядә аудиога яздыру, җырларга видеоклиплар төшерү, продюсерлык үзәкләре) көчле үсеш ала. «Татар җыры», «Созвездие-Йолдызлык», «Татар моңы» һ.б. фестивальләр зур уңыш б-н бара.

Татарстанның башкаласы актив үсеш кичерүче халыкара муз. культура үзәге булып тора. *Шаляпин Ф.И. исемендәге опера фестивале, Нуриев Р. исемендәге классик балет фестивале,* «Казан көзе» («Казанская осень») опера фестивале, халыкара *«Европа-Азия»,* С.Гобәйдуллина исем. «Конкордия» заманча музыка фестивальләре, «Рахлин сезоннары» («Рахлинские сезоны») һәм «Ак сирень» («Белая сирень») музыка фестивальләре киң танылу ала; музыка сәнгатенең төрле юнәлешләре буенча даими рәвештә халыкара, бөтенроссия, респ-ка конкурслары һәм фестивальләр (к. *Театр фестивальләре*) оештырыла. Казан консерваториясе, Казан мәдәният ин-ты, Казан ун-тының Л.Толстой исем. Филология һәм мәдәниятара багланышлар ин-ты, Казан консерваториясе каршындагы Махсус урта музыка мәктәбе; Казан, Әлмәт һәм Түбән Кама музыка көллиятләре, Чаллы сәнгать уч-щесе кебек югары һәм урта проф. белем бирә торган уку йортлары муз. культура үсеше өчен төп нигез булып тора. Респ-када музыка сәнгате өлкәсендә өстәмә белем бирүче 124 тән артык учреждение эшли, аларда 45 меңнән күбрәк бала белем ала (2013).

Традицион һәм заманча татар муз. культурасы Л.В.Бражник, Я.М.Гиршман, В.Р.Дулат-Алиев, А.Л.Маклыгин, М.Н.Нигъмәтҗанов, З.Н.Сәйдәшева, Ф.Ш.Салитова хезмәтләрендә анализлана.

**Театр сәнгате.** Казанда халык алдында театраль тамашалар б-н чыгышлар ясый башлау 18 йөзгә карый: 1726 елдан славян-латин мәктәбендә (алга таба семинария) ел саен «комедия акцияләре», 1760 тан гимназиядә укучылар һәм укытучылар катнашында спектакльләр уздырыла. Шулай ук крепостной театрлар оеша (мәс., Зөя өязенең Юмат авылында), шәһәр һәм авыл дворяннары утарларында «йорт спектакльләре» куела. 1791 дә Казанда даими эшләүче халык театры ачыла. Труппаның сәнгать җитәкчесе — элекке Петербург актёры В.Р.Бобровский; ул, рус драматургиясе репертуарына нигезләнеп, актёрлардан тормышчан, дөреслеккә туры килә торган башкару таләп итә. 19 йөз башында театр сәнгатенең формалашуы һәм үсүендә крепостной һәм ялланган актёрлардан торган крепостной театр нигезендә төзелгән һәм Казан үзәгендә үз бинасында драматик һәм муз. спектакльләр күрсәткән *Есипов театры* әһәмиятле роль уйный. Техник казанышлар файдаланылган күз явын алырлык сәхнә бизәлеше, оркестр б-н башкару, актёрларның проф. уеннары әлеге театр спектакльләрен шәһәрнең мәдәни тормышында күренекле вакыйга итә, Казан тамашачысында сәнгати зәвык тәрбияләүдә аның йогынтысы зур була. П.А.Плавильщиков, П.С.Мочалов, М.С.Щепкин, А.Е.Мартынов кебек танылган Мәскәү һәм Петербург актёрларының гастрольләре, 19 йөзнең 1 нче яртысында аларның Казан труппасы спектакльләрендә катнашуы Казан актёрларының проф. осталыкларын үстерүгә, алар иҗатының идея һәм гражданлык эчтәлеген баетуга булышлык итә. Казан театры сәхнәсендә реалистик сәнгатьне ныгытуда *театр тәнкыйте* зур роль уйный. 1850 еллар уртасыннан Казан матбугатында Казан ун-ты профессорларының аналитик мәкаләләре урын ала, аларда актёрлар уены мәктәбе, аның тормыш дөреслегенә туры килүенең мөһимлеге, актёрның тамашачы алдында җаваплылык тотуы хакында көчле бәхәсләр алып барыла. 1845–49 да дәүләт акчасына хәзерге Ирек мәйданы терр-ясендә таштан театр бинасы төзелә, бу үз чиратында шәһәрне даими рәвештә театраль тамашалар б-н тәэмин итү, илнең иң яхшы театр антрепренёрлары б-н килешүләр төзү мөмкинлеге тудыра. 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башы дәвамында Н.К.Милославский, П.М.Медведев, М.М.Бородай, Н.И.Собольщиков-Самарин, В.В.Образцов кебек антрепренёрлар эшчәнлеге нәтиҗәсендә Казан Россиянең иң зур театр үзәкләреннән берсе буларак дан казана. Бу чорда Казан сәхнәсендә исемнәре рус театры тарихына кереп калган актёрлар К.А.Варламов, В.Н.Давыдов, А.П.Ленский, М.В.Лентовский, В.А.Макшеев, М.Г.Савина, П.А.Стрепетова, М.И.Писарев, М.Т.Иванов-Козельский, В.И.Качалов, А.И.Каширин, В.Ф.Комиссаржевская, Е.О.Любимов-Ланской, М.М.Тарханов чыгышлар ясыйлар. 1874 тән даими опера сезоннары башлана (бу — Казанда опера театры барлыкка килүне раслаучы дәлил). 20 йөз башында яңа театр биналары, аерым алганда, Алафузов, Яңа (Татар драма һәм комедия театры), Зур (хәзер Казан Зур драма театры) театрлар төзелә, алар берничә театр труппасына бер үк вакытта шәһәрнең төрле урынында спектакльләр күрсәтү мөмкинлеге бирә.

20 йөз башы татар проф. театрына нигез салыну б-н билгеле. Аның тууында 1907 дә ачылган *Шәрекъ клубы* сизелерлек роль уйный, анда әдәби кичәләр уздырыла, татар һәм рус телләрендә спектакльләр куела. Театр тамашалары татар интеллигенциясе мохитендә дә, ш.у. төрле мәдрәсәләрдә дә популяр була. 1907 дән Казанда, Казан губернасы шәһәрләрендә Г.Кариев җитәкчелегендәге *«Сәйяр»* күчмә татар театр труппасының даими чыгышлары башлана. Беренче татар актёрлары Г.Болгарская, С.Гыйззәтуллина-Волжская, В.Мортазин-Иманский, М.Мутин, Н.Сакаев, З.Солтанов, Н.Таждарова, Б.Тарханов, К.Шамил, Ш.Шамильский, Камал I, Камал II, Ф.Ильская һ.б. милли театр сәнгате мәктәбе



Казан циркы.



**ТР театрлары.** 1. Г.Камал исем. Татар академия театры; 2. М.Җәлил исем. Татар опера һәм балет театры; 3. В.И.Качалов исем. Казан Зур драма театры; 4. Казан яшь тамашачылар театры; 5. Әлмәт татар драма театры; 6. К.Тинчурин исем. Татар драма һәм комедия театры; 7. Минзәлә татар драма театры; 8. Чаллы татар драма театры.

оештыралар, аның алга таба үсеш юлларын билгелиләр.

1919 дан театр эше дәүләт карамагына күчә. Эшләп килүче хосусый антрепризалар б-н беррәттән Халык мәгариф комис-тының театр бүлегенә буйсынган *үрнәк театрлар* — Совет Зур театры (к. *Казан Зур драма театры*), опера театры, Елга аръягы эшчеләр театры (к. *«Алафузов театры»*) оеша; элек эшләгән *«Сәйяр», «Нур», «Ширкәт»* күчмә татар театр труппалары актёрларыннан Беренче татар дәүләт театры төзелә, 1926 да ул акад. статусы ала (к. *Татар академия театры*). 1920 еллар яңа театраль формалар туу, иҗтимагый революцион үзгәрешләрне чагылдыра алган яңа сәнгатьчә сурәтләү чараларын актив эзләү б-н билгеләп үтелә. Эшче яшьләр театрлары (к. *ТРАМ*), тәҗрибә театр төркемнәре («Кызыл блуза», «Җанлы газета», Хәзерге заман театрының Казан тәҗрибә остаханәсе һ.б.) таралыш ала, Чистайда, Алабугада театрлар ачыла. Актёрлар әзерләү өчен, студияләр төзелә, алар нигезендә 1923 тә Татар театр техникумы (к. *Казан театр училищесе*) барлыкка килә. 1930 елларда респ-ка шәһәрләрендә, авыл тамашачысына хезмәт күрсәтү максатыннан, күчмә театрлар челтәре оеша; соңыннан аларның күбесе дәүләт театры статусы ала (к. *Минзәлә татар драма театры, Бөгелмә рус драма театры, Татар драма һәм комедия театры, Әлмәт татар драма театры*). 1932 дә Үзәк пионерлар клубы каршында ТЮЗ, рус һәм татар төркемнәреннән торган курчак театры оеша, соңрак алар нигезендә дәүләт театрлары (к. *Казан яшь тамашачылар театры, Татар курчак театры «Әкият»*) барлыкка килә. 1939 да *Татар опера һәм балет театры* ачыла, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге (к. *Татарстан Республикасының Театр эшлеклеләре берлеге*) төзелә, 1940 та *Актёрлар йорты* ачыла.

Бөек Ватан сугышы елларында Казан театрлары актёрлары концерт бригадалары составында фронтка баралар, госпитальләрдә хезмәт күрсәтәләр, хәрби техника җитештерү өчен акча җыялар, бер үк вакытта яңа спектакльләр чыгаруны дәвам итәләр. 1945–46 да респ-ка театрлары Бөтенсоюз рус классикасы спектакльләре смотрларында актив катнаша. Мәскәүдә узган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы (1957) Татарстанда театраль культура үсешенә йогынты ясаган зур вакыйга була, аны үткәрүдә проф. һәм үзешчән (һәвәскәр) театр коллективлары катнаша. Үзешчән театр сәнгате киң тарала, 1950–70 тә ул аеруча көчле үсеш ала; театр коллективлары мәдәният сарайлары һәм йортлары каршында, уку йортларында, пр-тиеләрдә оеша; үзешчән театр сәнгате смотрлары уздырыла, иң яхшы театрларга халык театры исеме бирелә (алар арасында Әтнә, Чистай, Алабуга, Чаллы татар халык театрлары һәм Казандагы ТАССРның 10 еллыгы исем. Мәдәният сараенда эшләп килүче театр аеруча популяр була).

1960 елларда үзәк матбугат битләрендә совет театрының үсеш юллары турында бәхәсләр бара, В.Э.Мейерхольд, Е.Б.Вахтангов, А.Я.Таировларның иҗат мирaслары аклана һәм театр практикасына кире кайтарыла, бу респ-кабызның театр сәнгате үсешенә дә йогынты ясый. *Репертуарга* К.Тинчурин, Г.Коләхмәтов, Ф.Бурнаш, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов пьесалары яңадан кайта, татар *театр сәнгате гыйлемендә* Г.Девишев, Г.Исмәгыйлев, С.Вәлиев-Сульва, Ә.Мәҗит кебек репрессияләнгән режиссёрларның иҗатлары өйрәнелә башлый. Казан театр уч-щесе һәм Казан мәдәният ин-ты ачыла, аларда үзешчән театр сәнгате режиссёрлары һәм проф. драма театры актёрлары әзерли башлыйлар. Бу еллар татар драматургиясе чәчәк аткан чор була; Г.Исхакый, Г.Камал,

М.Фәйзи, Ш.Камал кебек татар театры классикларының әсәрләре б-н беррәттән Н.Исәнбәт, М.Әмир, Х.Вахит, Т.Миңнуллин, А.Гыйләҗев, Ш.Хөсәенов, И.Юзеев пьесалары да милли театр репертуарының нигезен тәшкил итә. Татар театрында режиссура сәнгате Ш.*Сарымсаков*, Г.*Йосыпов*, К.*Тумашева*, Р.*Тумашев*, С.*Өметбаев*, Г.*Хөсәеновның* иҗат практикалары нигезендә формалаша. Респ-када театр сәнгате үсешенә үз тирәсенә драматургларны туплаган, сәхнә осталары коллективын җыйган, берничә буын яшь актёрлар тәрбияләгән мәшһүр реж. М.Х.*Сәлимҗановның* эшчәнлеге бәяләп бетергесез зур йогынты ясый. Аның җитәкчелегендә Татар акад. театры илнең әйдәп баручы театр коллективлары рәтенә чыга. Ул куйган «Зәңгәр шәл», «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин), «Әни килде» (Ш.Хөсәенов), «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин) спектакльләре театр сәнгатендә гомумроссия масштабындагы вакыйгага әверелә. Россия һәм чит ил шәһәрләренә даими рәвештә гастрольләр б-н чыгу, театр фестивальләрендә катнашу Татарстанның театр сәнгатен дөньяның бик күп илләрендәге киң катлау тамашачыларга ирештерә. 20–21 йөзләр чигендә театр сәнгатенә яңа иҗади көчләр килеп керә: режиссёрлар Ф.Бикчәнтәев, Р.Заһидуллин, Р.Әюпов, драматурглар Р.Хәмид, З.Хәким, Д.Салихов, М.Гыйләҗев, И.Зәйниев; моңа 2002 дән драматурглар өчен ел саен уздырыла торган «Яңа татар пьесасы» конкурсы да зур этәргеч була. 1980–90 елларда респ-када театр фестивальләре — Шаляпин Ф.И. исем. опера фестивале (1982 дән), Нуриев Р. исем. классик балет фестивале (1987 дән), Тинчурин К. исем. театр фестивале (1992 дән) уздырыла башлый, соңыннан алар халыкара статус ала; төрки халыкларның халыкара «Нәүрүз» театр фестивале аерым әһәмияткә ия. Анда ТР театр коллективларыннан тыш Төркия, Әзәрбайҗан, Казакъстаннан килгән театрлар, ш.у. РФ респ-калары һәм өлкәләре театрлары да катнаша. Тәҗрибә алмашуда Мәскәү, С.-Петербург һ.б. шәһәрләрдән танылган театрларның гастрольләр б-н килүе зур роль уйный. Г.Камал исем. Татар акад. театрында куелган «Кара чикмән» спектакле (реж. Ф.Бикчәнтәев) 2005 тә «Нәүрүз» театр фестивалендә барлык төп номинацияләрдә дә җиңүгә ирешә. 2007 дә Бөтенроссия «Театрның музыкаль йөрәге» («Музыкальное сердце театра») милли фестивалендә «Кара чикмән» — иң яхшы спектакль, Ф.Бикчәнтәев — иң яхшы режиссёр, И.Хәйруллин ирләр ролендәге иң яхшы артист булarak бәяләнә.

**Кино.** Беренче кинематограф сеанслары Казанда 1897 елда була; 1898 дә җирле кинематограф үзенең тәүге киноларын төшерә башлый. 1908 дә Казанда 8 хосусый стационар кинотеатр эшли, 19 кунакханә, ресторан һәм трактирда үзләренең кино күрсәтү җайланмалары була. 1915 кә Казанда кинотеатрлар саны 16 га җитә. Чистай шәһәрендә В.Г.Безчастнов (1912 дә) һәм И.Т.Токарев (1913 тә), Мамадыш өязенең Кукмара авылында мещан Н.И.Юзиев (1914 тә) тарафыннан кинотеатрлар ачыла. 1909 дан Казанда кинокартиналарны прокатка бирү оешмалары эшли башлый, Мәскәү кинематография конторалары бөтен Идел буе төбәге кинотеатрларын илебездә һәм чит илләрдә җитештерелгән фильмнар б-н тәэмин итүче үз вәкиллекләрен ача. Бер үк вакытта шәһәрнең аеруча зур вакыйгаларына багышланган фильмнар төшерелә: «Казан гарнизоны гаскәрләренең тантаналы парады», «Кышны озату бәйрәмендә Казан», «Ослан. Каекларда узышу», «Казан авиация атналыгы», «Казанда аеклар бәйрәме», «Кышкы автомобиль ярышы» һ.б. 1920 дә — ТАССР Советларының 1 нче съезды, 1921 дә — Гражданнар сугышы вакыйгаларына, 1924 тә — А.В.Луначарскийның Казанга килүенә багышланган фильмнар, 1926 да кинооператор К.Ф.Мотков тарафыннан Сабан туе бәйрәме төшерелә. 1924 тә «кино аша эшчеләр, кызылармиячеләр һәм крәстияннәрнең мәдәни ихтыяҗларына хезмәт итүне» максат итеп куйган һәм кино җитештерү, кинопрокат эшләре б-н шөгыльләнгән «Татарстан кинематография берләшмәсе» (*«Таткино»*) АҖ оеша. Респ-ка 8 районга бүленгән була, аларның һәркайсына киномеханик б-н күчмә кино җибәрелә. Күчмә кинолар 502 мең кешедән торган 173 авылга хезмәт күрсәтә; айга 20 ләп фильм күрсәтелә. 1927 дә реж. Ю.В.Тарич «Таткино» б-н берлектә Казанда *«Булат батыр»* тарихи фильмын төшерә, анда Казан театрлары актёрлары да катнаша. 1928 дә «Таткино» катнашучы хокукында *«Востоккино»* АҖ составына керә. 1929–30 да Татарстан кинематографистлары б-н берлектә «Татарстан (Дүрт елга иле)», «Комета», «Татарстанның 10 еллыгы» фильмнары төшерелә.

«Востоккино»ның Татарстан бүлегендә үзләренең кино төркеме барлыкка килә, сценарий цехы оеша, «Өндәү», «Икмәк өчен көрәш», «Иж минераль сулары», «Бөтентатар Советлар съезды» фильмнары төшерелә. 1932 дә «Востоккино»ның Татарстан бүлеге «Роскино» карамагына күчерелә, Казанда «Союзкинохроника»ның үз студиясе булган Татарстан бүлеге оеша, әзлекле рәвештә кино төшерү эше башланып китә. Бөтенсоюз экраны өчен 50 документаль фильм һәм якынча 100 сюжет чыгарыла. 1961 дә студия, мөстәкыйль пр-тие статусы алып, *Казан кинохроника студиясенә* үзгәртелә. Бу вакытка кинематографистларның үз кадрлары — режиссёрлар, операторлар, кино сценарийлары язучылар әзерләнә (В.И.Беспалов, Н.К.Вәлитов, В.Е.Игнатюк, В.Г.Миронов, Н.А.Морозов, М.А.Разбежкина, А.С.Стремяков, Э.Х.Үтәгәнов, Х.Ф.Фәхретдинов, К.В.Аристов, Ю.К.Гвоздь, М.Ә.Залюшев, В.А.Кузьмин, В.И.Севастьянов, Р.И.Копосов, Р.А.Рубцова).

ТР кинематографистлары тарафыннан төшерелгән фильмнар халыкара кино фестивальләрендә катнаша, күп кенә дәрәҗәле дипломнар һәм призлар б-н бүләкләнә. 2005 тән Казанда *Халыкара мөселман киносы фестивале* (2010 га кадәр *«Алтын мөнбәр»*) уздырыла; анда Төркия, Иран, Мисыр, БДБ илләре, Европа, Америка кинематографистлары да катнаша. Кинокартиналар б-н тәэмин итү һәм аларны прокатка бирү б-н «Татаркино» дәүләт учреждениесе (2006 га кадәр — ТР Мәдәният министрлыгы каршындагы Кинематография идарәсе) шөгыльләнә. Аның Бөгелмә, Чаллы, Чистай шәһәрләрендә ф-лары, ш.у. 200 гә якын авылда кино күрсәтү җайланмаларына һәм 19 кинотеатрга хезмәт күрсәтүче 33 район учреждениесе була.

Җиһазлар искерү сәбәпле заманча форматта фильм күрсәтү мөмкинлеге булмаганга, 1990 елларда респ-каның авыл җирлегендә халык алдында кино күрсәтү туктала. Бер үк вакытта Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләрендә цифрлы кино урнаштырылган күп заллы хосусый кинотеатрлар ачыла.

Соңгы вакытта кино сәнгате өлкәсендә нәфис фильмнар җитештерү эшен үстереп җибәрү сизелерлек активлаша башлады. Татарстан Респ-касы тамашачыларына V Халыкара мөселман киносы фестивалендә «Иң яхшы оператор эше» (оператор Э.Ситдыйков) номинациясендә җиңү яулаган «Өч аяклы ат» («Трёхногая кобыла», реж. Н.Җамалиева, 2009) фильмы тәкъдим ителә. «Бибинур» (реж. Ю.Фетинг, 2010) фильмы VI Халыкара мөселман киносы фестивалендә гран-при ала һәм иң яхшы роль өчен актриса Ф.Әхтәмовага (Бибинур карчык ролендә) бүләк бирелә. Кыска метражлы «Югалту» (реж. И.Ягъфәров, 2012) уен фильмы VIII Халыкара мөселман киносы фестивале конкурс программасында катнаша һәм «Милли традицияләрне һәм татар телен саклауга өлеш керткән өчен» химаяченең махсус бүләгенә лаек була. 2015 тә Казан, ш.у. ТРның башка шәһәрләре экраннарында һәм «ТНВ» телевидениесе каналында Г.Әпсәләмов романы буенча «Ак чәчәкләр» (реж. Р.Әюпов) нәфис фильмы күрсәтелә.

**Сынлы сәнгать һәм бизәлеш сәнгате**. Татарстанның 1920 еллар башында формалашкан сынлы сәнгать һәм бизәлеш сәнгате татар халкының Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы мәдәнияten тудырган күпгасырлык мирасы традицияләренә таяна. 16 йөз уртасыннан төбәктә проф. *нәкышь сәнгате, графика* һәм *скульптура* мәктәбен оештыруда әйдәп баручы роль уйнаган рус сәнгати мәдәнияте үсеш ала. Бер үк вакытта төбәктә яшәүче халыкларның традицион бизәлеш сәнгате дә алга китә (к. *Бизәлеш сәнгате, Сынлы сәнгать, Рус халык сәнгате, Татар халык сәнгате*). 1920 еллар сәнгатенең сәяси *плакат*, китап, газета-журнал һәм альбом графикасы, *монументаль-бизәлеш сәнгате*, «җитештерү» һәм бизәү сәнгате (к. *Дизайн*) кебек агитация-гаммәви төрләренә көчле этәргеч бирә. Станлы нәкышь, графика һәм скульптурада төп урынны тарихи-революцион, көнкүреш һәм портрет (яңа чор батырлары) жанрлары ала. Киң халык катлавына сәнгать хәзинәләренә юл ачкан музейлар (ТАССРның Үзәк музее, *Шәрекъ халыклары сәнгате музее*, Кооперация һәм вак һөнәрчелек сәнәгате музее, 1920–27) һәм күргәзмәләр эшчәнлеге (Казандагы 1 нче Бушлай картиналар күргәзмәсе, 1918; Шәрекъ халыклары мәдәнияте күргәзмәсе, 1 нче




**ТРда скульптура һәйкәлләре.** 1. Н.И.Лобачевский һәйкәле. Скульпторы И.Л.Диллон, архитекторы Н.Н.Игнатьев. 1896; 2. Студент Владимир Ульянов һәйкәле. Скульпторы В.И.Цигаль, архитекторы В.В.Калинин, 1954; 3. Г.Тукай һәйкәле. Скульпторлары С.С.Ахун, Л.Е.Кербель, Л.М.Писаревский, архитекторы Л.Н.Павлов. 1958; 4. Муса Җәлил һәйкәле. Скульпторы Е.В.Цигаль, архитекторы Л.Г.Голубовский, 1966; 5. А.М.Бутлеров һәйкәле. Скульпторы Ю.Г.Орехов, архитекторлары В.А.Петербуржцев, В.А.Степанов, М.Х.Агишев, 1978; 6. Мулланур Вахитов һәйкәле. Скульпторы Ю.Г.Орехов, архитекторлары В.А.Петербуржцев, А.В.Степанов, М.Х.Агишев, 1985; 7. Ф.И.Шаляпин һәйкәле. Скульпторы А.В.Балашов. 1999; 8. Салих Сәйдәшев һәйкәле. Скульпторы М.М.Гасыймов, архитекторы Г.А.Бакулин. 2005; 9. Кол Гали һәйкәле. Скульпторлары А.В.Балашов, А.М.Миңнуллина, архитекторы Р.М.Нургалиева. 2005 (барысы да – Казанда); 10. Нефтьчеләр һәйкәле. Әлмәт шәһәре. Скульпторлары А.И.Бельдюшкин, А.В.Рыбкин, В.А.Климов. 1985; 11. Н.А.Дурова һәйкәле. Скульпторы Ф.Ф.Лях. 1991; 12. Д.И.Стахеев һәйкәле. Скульпторлары А.В.Головачёв, А.В.Демченко. 2003 (икесе дә – Алабуга шәһәре).

Дәүләт сәнгать һәм фән күргәзмәсе, икесе дә — Казанда, 1920; «Казан, алга», 1924; «Казан плакаты», 1929 һ.б.) киң колач җәя. Дәүләт югары иректе сәнгать остаханәләрендә (соңрак — *Казан сынлы сәнгать уч-щесе*) алга таба респ-каның заманча проф. сынлы сәнгатенә нигез салачак нәкышьчеләр һәм сынчылар белем ала. Башлангыч чорда рәссамнар иҗаты Пролеткульт идеологиясе б-н бәйле «сул» модернистик юнәлешләрдән алып рус «күчмә» реализм сәнгатенә кадәр җәелә («*Подсолнечник*», «*Всадник*», «*Октябрь*», *ТатЛЕФ, СУЛФ, ТатАХХР* берләшмәләре). Нәкышь, графика, театр декорациясе сәнгатенең образлы-пластик мөмкинлекләрен киңәйткән рәссамнар П.П.Беньков, М.В.Барашов, Д.Н.Красильников, А.Н.Коробкова, Ш.Н.Мөхәммәтҗанов, А.Г.Платунова, И.Н.Плещинский, Н.М.Сокольский, Ф.Ш.Таһиров, Б.И.Урманче, Н.И.Фешин, Д.М.Фёдоров, С.С.Федотов, К.К.Чеботарёв, Ф.П.Гаврилов 1920 еллар сәнгатендә якты эз калдырылар (аларның иҗаты хәзерге вакытта да актуальлеген югалтмый). 1930 еллар башыннан 1980 еллар ахырына кадәр респ-ка сәнгате соц. реализмны нәфис иҗатның бердәнбер юлы дип игълан иткән дәүләтнең идеологик күзәтүе астында үсә. КПССның Татарстан өлкә ком-ты бюросы карары б-н 1936 да Казанда ТАССРның Рәссамнар берлеге оеша; матди-җитештерү базасы буларак «Татхудожник» остаханәләре ачыла (к. *Татарстан Республикасы сәнгать фонды*). Шул ук елда Яшел Үзән шәһәрендә Совет Татарстаны рәссамнарының беренче картиналар күргәзмәсе оештырыла. Сәяси репрессияләр һәм 1930–40 елларда талантлы рәссамнарның респ-кадан китүе сәбәпле, сынлы сәнгатьтә әле 1920 еллар ахырында ук тоемланган кризис башлана. Гамәли сәнгать үсешендә 1920–1930 еллар башындагы беркадәр күтәрелеш төшенкелек процесслары б-н алмашына: халык осталары — вак һөнәрчеләр эшчәнлекләрен туктатырга мәҗбүр булалар, сәнгать һөнәрчелеге юкка чыга (Питрәч чүлмәк ясаучылары, Чабакса тимерчеләре, Балык Бистәсе челтәр бәйләүчеләре һәм зәргәрчеләре).

Респ-када рәссамнар эшчәнлеге Бөек Ватан сугышы чорында активлаша, аның беренче көннәреннән үк Казанда басмаханә (рәссамнар Б.М.Әлминов, Р.Ф.Сәйфуллин) һәм трафарет буенча кулдан җыю (И.Е.Бобровицкий, Э.Б.Гельмс, А.А.Прытков, Н.М.Сокольский) ысуллары б-н сәяси плакатлар чыгару җайга салына («Окно сатиры» номерлары). Фронтта һәм тылда нәкышь (В.К.Тимофеев, К.Е.Максимов, Д.Г.Булат, Г.В.Житков), графика (Е.В.Зуев, В.В.Попов, А.М.Родионов, Х.Г.Якупов һ.б.) һәм скульптура (С.С.Ахун, Казанда вакытлыча эшләгән немец антифашисты В.В.Ламмерт) әсәрләре иҗат ителә. Күп кенә талантлы рәссамнар сугышта һәлак була (П.М.Байбарышев, Н.К.Вәлиуллин, Г.Я.Мусин, А.Г.Силантьев һ.б.). Сугыштан соңгы чорда нәфис сәнгать 1940 еллар ахыры — 1950 еллар башына хас тантана-күтәренкелек рухындагы картиналардан (моның ачык үрнәге — Л.Г.Фәттахов һәм Х.Г.Якуповның 1950 елда Сталин бүләгенә лаек булган «В.И.Ленинның Татарстан АССРны төзү турындагы Декретка кул куюы» масштаблы картинасы) стиль юнәлешләренең төрлелеге б-н «Сталин реализмы» кысаларын үтеп чыккан «Хрущёв җепшеклеге» әсәрләренә таба үсә. 1960–70 елларда респ-када талантлы нәкышьчеләр коллективы туплана, темалары заман рухына тәңгәл станлы картиналар көчле үсеш ала, милли үзенчәлекле картиналар өлкәсендә эзләнүче рәссамнарның төп юнәлешләре ачыклана. Милли-төбәк нәкышь мәктәбенең көчле вәкилләре, башлыча, Казан рәссамнары Е.В.Зуев, Р.Ә.Килдебәков, В.И.Куделькин, С.О.Лывин, Р.В.Нурмөхәммәтов, А.Л.Прокопьев, И.В.Рәфыйков, А.М.Родионов, Е.А.Симбирин, М.Г.Усманов, Л.Г.Фәттахов, Х.Х.Хәйдәров, И.М.Хәлиуллов, Х.Г.Якупов, ш.у. Н.Г.Бикташев (Чаллы ш.) һәм М.Х.Хәйретдинов (Лениногорск ш.) була. 1960 еллардан башлап, илнең әйдәп баручы сәнгать югары уку йортларын тәмамлап респ-кага килгән графиклар иҗаты ш.у. төрләр һәм жанрлар байлыгы б-н аерылып тора. Линогравюра, литография, офорт, пастель, акварель жанрлары тергезелә, агачка уеп кисү, монотипия, ксилография (индустриаль, тарихи, сәяси, пейзаж, портрет һәм фольклор темаларына багышланган) үзләштерелә. Китап һәм станлы графикада Б.М.Әлминов, Р.Ә.Госманов, Э.Я.Зарипов, В.В.Карамышев, Е.В.Киселёва, И.К.Колмогорцева, С.М.Кульбака, М.К.Мавровская, В.А.Попов, Г.Г.Рахманкулова, Э.Г.Ситдыйков, Т.Г.Хаҗиәхмәтов, И.Л.Язынин уңышлы эшлиләр. Аларның иҗатында татар халык мәдәнияте б-н кызыксыну, сәнгать телендә декоративлык, композицияләрнең бизәклелегенә омтылу көчәя. «*Чаян*» ж-лы б-н хезмәттәшлек иткән сатирик графика рәссамнары И.К.Әхмәдиев, Э.Б.Гельмс, Ю.А.Денисов, Л.Я.Елькович, Л.Х.Насыйров, И.С.Хантимеров халыкара танылу ала. 1951 дә Мәскәүгә күчеп киткән күренекле скульптура остасы С.С.Ахунга алмашка станлы картиналарда һәм ихтыяҗ аеручa зур булган монументаль жанрда (к. *Монументаль сәнгать*) талантларын күрсәткән үзенчәлекле рәссамнарның яңа плеядасы килә (Б.И.Урманче, Р.Х.Нигъмәтуллина, В.М.Маликов, Н.И.Гаделев, А.Х.Әбдрәшитов, Ә.К.Бәширов, В.И.Рогожин).

1970–80 елларда Татарстан Рәссамнар берлегендә «Татарстан нефте», «КамАЗ», «Авыл» иҗат төркемнәре оеша. Бу Казанда гына түгел, ш.у. Чаллы, Түбән Кама, Лениногорск, Бөгелмә, Алабуга, Әлмәт, Яшел Үзән һ.б. шәһәрләрдә дә нәкышь, графика һәм скульптура кебек төрләрнең үсешенә китерә (сәнгать мәктәпләре һәм уч-щеләре ачыла, күргәзмәләр уздырыла). Рәссамнар берлеге үзенчәлекле әсәрләр б-н килеп кергән яңа осталарга байый, нәкышь һәм графиканың образлы-пластик мөмкинлекләрен киңәйтә (А.Ә.Абызгилдин, Н.У.Әлмиев, В.П.Аршинов, З.Ф.Гыймаев, И.К.Зарипов, Р.Ә.Килдебәков, К.Ә.Нәфыйков, Ш.Г.Нигъмәтуллин, Р.Т.Сафиуллин, В.Н.Скобеев, Б.И.Урманче, В.К.Фёдоров, Ш.М.Шәйдуллин һ.б.). Казанда, респ-каның сәнәгать һәм нефть үзәкләрендә шәһәр төзелешенең киң колач алуы, яңа җәмәгать корылмаларының сафка басуы монументаль-бизәлеш сәнгатенең (ташка, цементка, агачка уеп кисү, дивар бизәге, *мозаика*, витраж, *гобелен* һ.б.) көчле үсешенә этәргеч бирә (Казандагы химиклар, төзүчеләр мәдәният сарайлары, Яшьләр үзәге, «Татарстан» кунакханәсе, Татар акад. театры, шәһәр яңы тимер юл вокзалы; Чаллыдагы «Энергетик» мәдәният сарае, «Батыр» кунакханәсе, Энтузиастлар проспекты; Түбән Камадагы 2 нче шәһәр хастаханәсе; Әлмәттәге «Нефтьче» мәдәният сарае; Бөгелмәдәге Техника йорты һ.б.). Монументаль сәнгать өлкәсендә махсус белем алган рәссамнар: И.Н.Башмаков, Р.Ә.Килдебәков, В.М.Маликов, Ш.Г.Нигъмәтуллин, В.К.Фёдоров һ.б. эшчәнлеге танылу ала. 1970 еллар ахырында — 1980 еллар уртасында рәссамнар алдына архит-ра һәм бизәлеш сәнгатенең синтезы мәсьәләсе килеп баса, дизайнның әһәмияте көчәя (Н.С.Артамонов, В.А.Нестеренко, З.Низамиев, Р.Т.Сафиуллин). Әлеге сәнгать төренең географиясе киңәя. Ул яңа төзелешләр б-н бәйле Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Лениногорск, Азнакай һ.б. шәһәрләрдә, шәһәр тибындагы Җәлил посёлогында актив үсә; рәссам-монументалистлар, бизәүчеләр отряды оеша (Р.Г.Агафонов, В.Я.Акимов, Д.Г.Рәхмәтуллин, К.М.Сафиуллин, И.М.Ханов һ.б.). Рәссамнар Э.Б.Гельмс, А.Б.Кноблок, Ә.Х.Нагаев, В.С.Никитин, П.Т.Сперанский, М.Г.Сутюшев, Ә.И.Тумашев — әлеге чорның театр бизәлеше сәнгате вәкилләре. 1980 еллардан башлап, яңа эстетика үсеше ягыннан да, техник чаралар үсеше ягыннан да сәхнә сәнгате мөмкинлекләре киңәя, махсус белем алган талантлы театр рәссамнары килә: Р.Х.Газиев, А.А. һәм В.Е.Губскийлар, Т.Г.Еникиев, Ә.Ә.Җәмилова, Н.Х.Кумысникова, С.Г.Скоморохов.

1970–80 елларда проф. *гамәли-бизәлеш сәнгатенең* керәч, каюлы күн, зәргәрчелек, гобелен, агачка уеп бизәк төшерү һ.б. төрләре үсеш ала (Б.А.Шубин, С.Д.Кузьминых, И.Н.Башмаков, Г.В.Богородская, С.В. һәм В.О.Ковалевскийлар, Р.Ә.һәм М.С.Килдебәковлар, О.А.Кульпин һ.б.), Арча шәһәрендәге, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогындагы халык сәнгате һөнәрчелеге пр-тиеләрендә, Казан сувенирлар ф-касында, Васильево посёлогы, шәһәр тибындагы Шәмәрдән посёлогы, Саба урман хуҗалыгы сувенирлар цехларында, Бөгелмә фарфор з-дында, *Кукмара киез итек-киез комбинатында*, Казан өйдә эшләүче осталар комб-тында эшләнмәләрне күпләп җитештерү җайга салына.

20 йөзнең соңгы чирегендә милли гореф-гадәтләрне (ш.и. мөселман мәдәнияте б-н бәйле булганнарын) яңадан торгызу хәрәкәте башлана, абстракционизм, постмодернизм, неопримитивизм һ.б. авангард агымнар барлыкка килә. Жанрлар һәм стиль диапазоны чикләре киңәя, сәнгатьнең яңа төрләре (инсталляция, объект, коллаж һ.б.) һәм традицион төрләре (хаттатчылык, шәмаил, ләүхә) барлыкка килә, дөньяга сәнгатьчә яңа караш формалаша, Казанда һәм Чаллыда — «Та-

тарстан рәссамнары берләшмәсе» (ТРБ), Казанда — «17 ле төркем», «Дастан», Чаллыда — «Ансваки», «Тамга», Яшел Үзәндә — «Ак Бассет», Әлмәттә — «ОКО» һ.б. иҗат берләшмәләре оештырыла. Реализмнан алып постмодернизмга кадәрге стиль агымнарының киң спектрын татар халкының һәм респ-ка тормышының үткәнен һәм бүгенгесен чагылдыру максаты берләштерә. Казан рәссамнары З.Ф.Гыймаев, Р.Г.Заһидуллин, И.К.Зарипов, Ә.Р.Ильясова, К.Ә.Нәфыйков, Р.Х.Нигъмәтуллина, В.И.Рогожин, И.Ә.Хәсәнов, Ф.Ш.Хәсьянова, Ш.М.Шәйдуллин һ.б.; Чаллылыдан В.Я.Акимов, В.В.Анютин, А.И.Вашуров, Б.Б.Грабенко, А.И.Дербилов, Г.М.Недовизий, А.А.Петров, З.С.Низаметдинов, К.М.Сафиуллин, Ю.Г.Свинин, В.И.Сынков, М.Ш.Хаҗиев, М.Г.Шәйдуллин, Х.М.Шәрипов; Түбән Камадан Г.Н.Капитов, Р.М.Мәрданшин, Ә.С.Фәтхетдинов; Алабугадан Ә.С.Миңнәхмәтов, Р.М.Сәлахов; Лениногорскидан М.Х.Хәйретдинов җитәкчелегендәге А.Г.Горюнов, Я.Г.Зиннәтуллин, О.А.Кульпин, Д.К.Садретдинов, А.И.Юдин һ.б.; Бөгелмәдән Ф.Е.Корнилов, Р.З.Круглякова, Б.Ш.Мәрдәнов, И.М.Насретдинов, Н.Н.Осокин, Д.К.Рәхмәтуллин; Әлмәттән: А.Р.Агафонов, В.И.Бушурова, Н.М.Горланов, Р.В.Гомәров, А.Ф.Косолапов, А.И.Максютин, Г.А.Стефановский, А.Г.Терентьев, С.З.Фәрхетдинов; Яшел Үзәннән Р.Ф.Галиуллин, А.К.Заһиров, М.А.Покалёв, Х.К.Сибгатуллин иҗаты — моның ачык шаһиты. Сынлы сәнгать үсешендә дәүләти һәм хосусый галереялар («Хәзинә», «Казан» милли мәдәният үзәге, «Ак Барс», «Эбиволь», «Камил» — Казанда; «Гадел» — Түбән Камада һ.б.) эшчәнлеге мөһим роль уйный. 1980, 1991 һәм 2013 тә Казанда «*Зур Идел*»нең 5, 7, 11 нче зона күргәзмәләре, Идел буе Болгар дәүләтенең ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга һәм Казанның 1000 еллыгына багышланган халыкара күргәзмәләр уздырыла. Респ-ка көненә багышланган сәнгать күргәзмәләре, «Нефть ягы» һ.б. төбәк күргәзмәләре даими үткәрелеп килә.

Бизәлеш сәнгате үсешенең хәзерге заман этабына әсәрләрнең милли формаларын халык сәнгате традицияләрен, төзүдә һәм дизайндагы актуаль тенденцияләрне үзләштерү аша эзләү хас. Бизәлеш сәнгате өлкәсендә проф. рәссамнардан тыш традицион кәсепләрне үстерүче халык осталары, махсус проф.-техник белемле сәнгать кәсепчелеге осталары һәм үзешчән рәссамнар эшли (Халык сәнгать һөнәрчелеге һәм кәсепчелеге үсеше үзәге, 2003 тә ТР МК каршында оештырылган Кәсепчелек палатасы тирәсендә берләшәләр). Каюлы күн һәм күнгә басма бизәк төшерү («Экоскин» ҖЧҖ, «Презент» АҖ, рәссамнар И.Х.Гайнетдинов, Н.Х.Кумысникова, Ә.Ә.Җәмилова), сәнгати текстиль: киез, гобелен, чигү, укалап чигү, аппликация (И.А.Галант, Н.Ә.Галәвиева, А.Н.Егоров, Д.Г.Рәхмәтуллин, Л.Ф.Фәсхетдинова, Х.М.Шәрипов), зәргәрчелек һәм металлны нәфис эшкәртү сәнгате (И.Н.Башмаков, И.А.Васильева, Т.В.Соловьёва, Ә.С.Шәмсетдинов), кием өлгесе һәм милли курчаклар конструкциясен әзерләү (А.М.Глебова, Р.И.Исхаков, Р.Р.Камалова, З.В.Мөхәммәтҗанова), агачка уеп кисү һәм бизәк төшерү (З.А.Низаметдинов, С.А.Федотов), керәч төрләре (Т.Н.Кривошеева, Н.В.Кузьминых, Х.Н.Латыйпов) үсеш ала; монументаль-бизәлеш төрләре арасында — дивар бизәге, мозаика, гипска уеп кисү, тукыма панносы; базар икътисады үсеше чорында сәнәгать һәм интерьер дизайны зур әһәмияткә ия була (Р.М.Абаев, А.П.Леухин, З.С.Низамов, А.Н.Лопаткин). Дини-гыйбадәт корылмаларының архит-ра-сәнгать ансамбльләре барлыкка килү — 20 йөз ахыры — 21 йөз башы монументаль-бизәлеш сәнгатенә хас үзенчәлек. Мәчетләр бизәүдә (Казанда «Колшәриф», Чаллыда «Тәүбә», Әлмәттә «Ринат» мәчетләре, Түбән Камада, Лениногорскида һ.б. шәһәрләрдәге җамигъ мәчетләр) *мозаика,* майолика, гипслы рельефлар, витраж, чиркәүләрдә дивар бизәге, ташка уеп бизәк төшерү, *агачка уеп кисү* һәм *агачка бизәк төшерү* кебек төрләр үсеш ала. Яңа тенденция барлыкка килә: рәссамнар, архитектор һәм дизайнерлар бергә эшлиләр (С.Ә.Мамлиева, А.М.Миңнуллина, А.А.Михайлов, Д.Р. һәм Л.В.Мусиннар, В.А.Нестеренко, Р.Н.Нургалиева, Ф.Г.Халиков, Н.Т.Хаҗиәхмәтов, Р.Н.Сәләхетдинов, А.Г.Саттаров һ.б.).

Сәнгать белеменең (классик төшенчәдә сынлы сәнгать теориясе һәм тарихының) башлангычы Казан ун-тында нәфис сәнгать каф. ачылу б-н бәйле (19 йөзнең 2 нче яртысы). Татар сәнгате өлкәсендә беренче тикшеренүләр 1920 еллар ахырында уза (П.М.Дульский, Е.П.Корнилов). Идел буенда татар сәнгатен фәнни нигезләгән галимнәрнең берсе — борынгы заманнардан алып 20 йөз башына кадәр татарларның сәнгать мирасы турында хезмәтләр язган сәнгать белеме д-ры Ф.Х.Вәлиев. Татарстанның рев-циягә кадәрге һәм хәзерге заман сынлы сәнгате (нәкышь, графика, скульптура) тарихы, рәссамнар иҗаты Мәскәүдә яшәүче сәнгать белгече С.М.Червоннаяның монографик хезмәтләрендә яктыртыла. Татарстанның бизәлеш һәм гамәли бизәлеш сәнгате теориясе һәм тарихы өлкәсендә тикшеренүләрне хәзерге вакытта Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова алып бара, сынлы һәм бизәлеш сәнгатенең аерым төрләренә караган мәсьәләләр Д.К.Вәлиева, Е.П.Ключевская, И.Ф.Лобашёва, Р.Р.Солтанова, Г.Н.Тулузакова, О.Л.Улемнова, Г.Р.Фәйзрахманова, Р.Г.Шаһиева, Р.И.Шәмсутов, Д.Д.Хисамова һ.б. хезмәтләрендә ачыла.

Респ-када экспозиция эшчәнлеген «*Хәзинә*» галереясы һәм Хәзерге заман сәнгате галереясы б-н бергә *ТРның Дәүләт Сынлы сәнгать музее*, Б.И.*Урманче* һәм Ә.Н.*Мәҗитов* музейлары, И.К.Зарипов галерея-студиясе б-н берлектә «*Казан*» *милли мәдәният үзәге*, К.А.Васильев картиналары галереясы, «*Туран*» фонды (барысы да — Казанда), Чаллыдагы һәм Әлмәттәге картиналар галереялары, *Алабуга тарих-архитектура һәм сәнгать музей-саклаулыгы*, *Яшел Үзән халык иҗаты һәм этнография музее*, Яңа Чишмә р-нының Зирекле авылындагы Халык иҗаты һәм көнкүреше музее алып бара.

Сынлы һәм гамәли-бизәлеш сәнгате өлкәсендәге һөнәри белемнәр Казан сынлы сәнгать уч-щесендә, Лениногорск муз.-сәнгать пед. көллиятендә, Чаллы социаль-пед. технологияләр һәм ресурслар ин-тының сәнгать һәм дизайн ф-тында һәм Казан (Идел буе) Федераль ун-тының дизайн һәм милли сәнгать кафедрасында, Казан мәдәният ин-тында бирелә. 2008 дә В.И.Суриков исем. Мәскәү академия сәнгать ин-тының Казан ф-лы ачыла. Респ-када 19 балалар сәнгать мәктәбе, рәсем ясау бүлекләре эшләгән 29 сәнгать мәктәбе бар. Иҗади казанышларга кызыксындыру өчен «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» (1940), «Татарстанның халык рәссамы» (1948) дигән мактаулы исемнәр, ТР Мәдәният министрлыгының Б.Урманче исем. бүләге (1998) булдырыла. Ш.у.к. *Сынлы сәнгать, Бизәлеш сәнгате, Сәнгать белеме*.

**Архитектура**. Ныгытылган һәм ныгытылмаган яшәү урыннары хәзерге Татарстан җирендә 10 йөзгә кадәр барлыкка килә. Идел буе Болгар дәүләте архит-расы, беренче чиратта аның саклану корылмалары архит-расы, шәһәрләр барлыкка килгәч үсеп китә. Болгар чорында, таштан төзү техникасын үзләштерү б-н (10–13 йөзнең беренче яртысы), таштан салынган саклану корылмалары калка башлый. 11–12 йөзләрдән таш кирмән — рибат манараларының берсе — «*Шайтан каласы*» манарасы сакланып калган (хәзерге Алабуга шәһәрендә). *Казан Кремлендә* болгар чоры кирмәненең ак таш дивары һәм капкалы манараның археол. калдыклары табылган. Таш корылмалар, кагыйдә буларак, берaз шомартылган ак таштан салынган. *Биләр шәһәрлегендә* Җамигъ мәчет, Шәрекъ тибындагы мунча калдыклары һ.б. сакланган.

Казан ханлыгы чорында монументаль архит-ра яңа стилистик сыйфатларга ия була. Казан кирмәне квадрат яки сигез почмаклы манаралары булган таш-агач диварлар б-н ныгытылган. Терр-ясендә сарай, Хан мәчете, *Нургали мәчете*, хан төрбәләре урнашкан, әйләнәсе таш диварлар һәм манаралар б-н корылган хан кирмәне булуы мәгълүм. Риваятьләргә караганда, Казанда хан кирмәненең чын бизәге булып *Колшәриф мәчете* саналган. Шәһәрдә ш.у. *Отыч мәчете*, «*Даир мунчасы*» һ.б. таш корылмалар булган.

16 йөз уртасыннан Казан ханлыгының монументаль архит-ра традицияләре өзелә. Татар архит-расы үсеше, асылда, авылда, өлешчә *татар бистәләренең* шәһәр корылмаларында дәвам итә. Төбәк терр-ясендә рус агач саклану архит-расы традицияләрендә төзелгән кальгалы чик буе киртәләре барлыкка килә. Мәскәү, Псков һәм Владимир архит-ра мәктәпләре традицияләрендә дини корылмалар — *чиркәүләр* һәм *монастырьлар* төзелә. Казанның воевода сарае, идарәханә, таможня биналары һ.б. кергән Кремль архит-ра комплексы элекке Казан ханлыгының яңадан кушылган терр-яләренең адм. үзәгенә әверелә. *Казан посады* һәм аны чолгап алган бистәләр радиаль бөҗра рәвешендә формалаша. 17 йөзнең 2 нче яртысыннан төбәк архит-расында гомумрус стиле — бизәкләп кирпеч салу, төсле бизәкләр, майолика, ялтыравык

чирәп һ.б. б-н аерылып торган «кирпечле бизәк» юнәлеше үсеш ала (әлеге юнәлеш Казандагы *Михляев йорты* архит-расында һ.б.да чагыла). 17 йөз ахырыннан кирпечле бизәк архит-расы ордерлы формалар б-н байый. 17 йөз уртасыннан шәһәр һәм шәһәр яны монастырьлары манаралы кирпеч диварлар б-н әйләндереп алына, алар эчендә кирпеч-таш чиркәүләр корыла. Казан Кремлендәге күпкатлы манараның (*Сөембикә манарасы*) төзелү вакыты XVI йөзнең беренче яртысыннан алып XVIII йөзнең беренче чирегe кысаларында тирбәлә. Ул шәһәрнең төп вертикаль корылмасына әверелә.

1730–50 елларда төбәктәге шәһәр диварлары сүтелә, бистәләр шәһәр корылмаларына кушыла. 18 йөз башыннан рус архит-расында «кирпечле бизәк» биналарга Европа күренеше бирүче *барокко* стиле б-н алмашына. 18 йөзнең 1 нче яртысында Казан Кремленең күренеше үзгәрә башлый. Ансамбль диварлары «карлыгач койрыгы» рәвешендә төгәлләнә, *Спас манарасына* яруслар өстәлә, һәм ул биек чатыр б-н очлана, өстәп башка манаралар да төзелә; ак таш һәм кирпеч диварлар штукатурлап агартыла. 18 йөзнең 2 нче яртысында Казан губернасында барокко стилендәге һәм татар дини архит-расының урта гасырлардагы традицион планлаштырылган-күләмле формаларындагы кирпеч мәчетләр төзелә башлый. Иске татар бистәсе беренче монументаль биналар — *Мәрҗани мәчете* һәм *Апанай мәчете* б-н бизәлә. Бөтен Россия терр-ясендә шәһәрләрне яңача планлаштыру һәм аларның төзелешен җайга салу б-н бәйле рәвештә, Казан (1768) һәм төбәкнең башка шәһәрләре өчен (19 йөзнең 1 нче чирегеннән) тәртипле генераль планнар эшләнә (к. *Шәһәр төзелеше*). Шәһәрләрдәге төзелешләр, башлыча, «үрнәк» планнар буенча бара. Казанның беренче архитекторы В.И.Кафтырев була (планны тормышка ашыру б-н җитәкчелек итә). 18 йөз ахырында — 19 йөз башында архитекторлар М.Е.Емельянов, Я.М.Шелковников, А.К.Шмидт проектлары буенча һәм алар җитәкчелегендә Казанда һәм башка шәһәрләрдә барокко стиленә алмашка килгән классицизм стилендәге беренче җәмәгать биналары төзелә. Казан губернасындагы шәһәрләрне даими нигездә яңача планлаштыру кирпеч һәм штукатурка киң кулланылган торак һәм җәмәгать биналарын үзгәртеп кору б-н үрелеп бара. 1830 еллар ахырыннан шәһәрләрдә төзелешләр типологиясе киңәя. 19 йөзнең беренче утызеллыгында шәһәрләр архит-расына классицизм һәм ампир керә башлый. Классицизм һәм ампир стилендәге корылмалар арасында *Гостиный двор, төрмә кальгасы*, шәһәр хастаханәсе, *хәрби госпиталь, «Иске таш» мәчет, Галиев мәчете* һ.б. (Казан), *Никола чиркәве, Покров чиркәве, Спас соборы* (Алабуга), Никола соборы (Чистай) һ.б. аерылып тора. Казанны архитекторлар П.Г.Пятницкий, М.П.Коринфский, Ф.И.Петонди проектлары буенча төзелгән *университет шәһәрчеге* комплексы баета.

1833 тә Россия империясе Эчке эшләр министрлыгының Юллар һәм җәмәгать биналары баш идарәсе карамагындагы Казан губернасы төзелеш комиссиясе оештырыла. Расланган планнар буенча төзү эшләре нәтиҗәсендә шәһәрләрдә төрле максатлардагы мәйданнар: Казанда адм. — *Иван мәйданы,* Театр мәйданы (таш түшәлгән һәм һәйкәлләр б-н бизәлгән), сәүдә — Печән (биредә беренче мәртәбә манарасы җирдә корылган гөмбәзле *Печән базары мәчете* төзелә), Балык, Икмәк базарлары һ.б. мәйданнар барлыкка килә.

1865 тә төзелешләрне җайга салу губерна идарәсенең төзелеш бүлегенә тапшырыла (шәһәрләрдә төзелешләр күләме арту сәбәпле). Шәһәрләрдә утарлы корылмалар урынына табышлы йортлар төзелеше киңәя. Архитекторлардан П.Е.Аникин, И.П.Бессонов, А.И.Песке, П.И.Романов, П.В.Тихомиров, В.К.Бечко-Друзин танылу ала.

19 йөз уртасында — 20 йөз башында Казан губернасы архит-расы эклектика һәм *модернның* төрле юнәлешләрендә үсә. *Романтизмның* таралуы җирле рус һәм татар буржуазиясенең үзләре яшәгән мохиткә милли мәдәният рухын һәм Европа архит-расының иң гүзәл казанышларын кертергә омтылышы б-н бәйле (Казандагы *Подуруева йорты,* Ушкова йорты һ.б.да стиль үзенчәлекләре ачыла). Иске татар бистәсендә *Апанаевлар йорты, Шамил йорты* аерылып тора; биналарның яңа типлары: тимер юл вокзалы, Алафузов театры, Казандагы Икенче ир балалар гимназиясе, Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-ты, Казан сынлы сәнгать мәктәбе, Казан руханилар академиясе, Казан ун-тының яңа клиникалары, Казан хәрби округы командующие йорты барлыкка килә.

Башка шәһәрләрдәге кебек үк Казанда да банклар, кунакханәләр, табыш йортлары, аерым зур йортлар (к. К.С.*Олешкевич* йорты, *Мюфке йорты, Оконишников йорты, Зобнин йорты* һ.б.), гыйбадәтханәләр (*Әҗем мәчете, Изге Екатерина кирхасы, Синагога, Покров иске дин тарафдарлары чиркәве*) төзелә; сәнәгать архит-расы үсеш ала (*Крестовниковлар заводы биналары комплексы, Александров И.В. варисларының сыра һәм сосла кайнату заводы комплексы*). 1909 да уздырылган *Казан халыкара күргәзмәсендә* төбәк тарихында беренче булып үзенчәлекле күргәзмә павильоннары корыла. Бу Казан губернасында сәнәгать үсешенең югары дәрәҗәгә ирешүен тану була. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында архитекторлар Л.К.Хрщонович, Ф.Р.Амлонг, Г.Б.Руш, К.Л.Мюфке, К.С.Олешкевич, Ф.Н.Малиновский, С.В.Бечко-Друзин һ.б. Казан губернасының архит-ра үсешенә зур өлеш кертәләр. Шулай ук авыл җирлегендә дә татар һәм рус халык архит-расы формаларында төзелешләр алып барыла. Аларда, халык традицияләре саклану б-н бергә, шәһәр архит-расы йогынтысында классик нигезләр барлыкка килә (*Бакиров Вәлиулла йорты, Даутов йорты,* Әсән-Елга мәчете һ.б. агач архит-ра истәлекләрендә чагыла).

1920–30 елларда биналар *конструктивизм* стилендә төзелә башлый (Казандагы *Матбугат йорты*). 1930 елларның 2 нче яртысында — 1950 еллар башында Татарстан архит-расында үзенә классицизм, милли һәм совет сәнгате сыйфатларын туплаган заманча неоклассицизм стиле өстенлек ала (Казандагы Татар опера һәм балет т-ры, «Победа» кинотеатры, Ленин исем. мәдәният сарае, ТАССР ВДНХсы биналары комплексы, вет. шәһәрчеге, торак йортлар һ.б.). Архитекторлар И.Г.Гайнетдинов, И.Ә.Вәлиев, П.А.Саначин, Г.И.Солдатов, П.Т.Сперанский һ.б. әлеге стиль вәкилләреннән саналалар. 1950–1980 еллар ахыры барлык төр биналар һәм корылмалар төзелешен индустрияләштерү (нигездә, стандарт проектлар буенча), сәнәгать комплексларын үстерү, чит илләр архит-расының прогрессив алымнарын актив үзләштерү, тарихи биналарны реконструкцияләү, җирле архит-ра мирасы һәм монументаль-декоратив сәнгатьнең традицион формалары исәпкә алынган яңа проектлар эшләү (Казандагы Елга вокзалы, Үзәк стадион, Спорт сарае һ.б.) б-н характерлана.

Тимер-бетон конструкцияләр з-дларын һәм йортлар төзелеше комб-тларын төзү панельләрдән һәм блоклардан күпләп торак төзелешенә күчәргә мөмкинлек бирә. 1970 елларда Татарстанда яңа шәһәрләр — Чаллы, Түбән Кама һ.б. корыла башлый; аларда совет шәһәр төзелешенең күпчелек теоретик эшләнмәләре һәм проектлары әзлекле рәвештә гамәлгә ашырыла. Әлеге шәһәрләрнең сәнәгать зоналары СССРда беренче тапкыр торак районнардан читтә корыла һәм тиз йөрешле трамвай юллары б-н тоташтырыла; шәһәрләр — тоташ алдан әзерләнгән генераль планнар буенча, ә торак районнар һәм микрорайоннар бер үк вакытта үсеш алган инфраструктура (балалар бакчалары, мәктәпләр, җәмәгать үзәкләре һ.б.) б-н төзелә. Микрорайоннар ирекле планлаштыру принцибы буенча, йорт кишәрлекләрен аерым ишегалларына бүлмичә, инсоляция һәм аэрация таләпләренә туры китереп корыла.

Архит-ра–археол. истәлекләрне тикшерү, реставрацияләү һәм фәнни реконструкцияләүгә зур игътибар бирелә (к. *Реставрация* (архит-ра), *Архитектура гыйлеме*). Хәзерге заман Татарстан архит-расында милли-төбәк үзенчәлекләре чагылышының тарихи-теоретик нигезләре эшләнә (С.С.Айдаров). Шәһәр үзәкләрен реконструкцияләү һәм төзекләндерү, офислар, биналар, сәүдә йортлары төзү, хосусый һәм үрнәк проектлар буенча уңайлы торак йортлар төзү, борынгы гыйбадәтханәләрне торгызу һәм яңаларын салу, иҗтимагый җәмәгать биналары төзелешенә чит ил фирмаларын җәлеп итү, заманча төзелеш материалларын файдаланып, чит илләр архит-ра-төзелеш эшләренең алдынгы тәҗрибәсен үзләштерү; Татарстан архит-ра тарихы үсешенең барлык чорларыннан төбәкләрдәге үзенчәлекле архитектур чишелешләрне эзләү, традицион формаларны иҗади кабул итү 1990 еллар архит-расының үзенчәлеге булып тора. Казандагы «*Рамазан*», «*Болгар*», «*Хозәйфә ибне әл-Ямәни*» мәчетләре, Серафим Саровский храмы комплексы, Алабуга «*Җамигъ*» мәчете, Чаллыдагы «Тәүбә» һәм «Ихлас» мәчетләре, «*Түбән Кама җамигъ мәчете*», Әлмәттәге Петропавел соборы шәһәрләрнең бизәгенә әверелә.

21 йөзнең беренче унъеллыгында Татарстан башкаласы һәм башка шәһәрләр тиңе булмаган иҗтимагый-сәүдә (Казандагы «Пирамида», «Божра», «Корстон», «Парк Хаус», «Тандем» комплекслары), спорт (Казандагы «Баскетхолл», «Татнефть-Арена», «Ракета»; Чаллы, Түбән Кама, Лениногорск, Алабугадагы, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогындагы яңа спорт сарайлары һәм стадионнар), дини корылмалар (Казандагы Колшәриф мәчете, Вера, Надежда һәм Любовь, Софья, Изге Кирилл чиркәүләре, католиклар чиркәве; Әлмәттәге Р.Р.Галиев исем. мәчет һәм Казан-Богородица соборы; Болгардагы Ак мәчет, Түбән Кама, Лениногорск, Бөгелмә, Баулы һ.б.дагы мәчетләр һәм православие чиркәүләре), адм.-офис комплекслары (Казандагы «Таиф» ЖЧЖ; Әлмәттәге «Татнефть» АҖ һ.б.) б-н байый.

2005 тә Казанда Казансу елгасы аша «Миллениум» күпере төзелә. «Суворов», «Магеллан», «Күкнең җиденче каты», «Кояшлы шәһәр» һ.б. заманча торак комплекслары Идел һәм Казансу елгалары ягыннан ТР башкаласы манзарасын үзгәртәләр. Казанда Татар «Әкият» курчак театрының яңа бинасы ачыла (2012, арх. С.Ә.Козлова-Мамлиева). Ләкин 2000 еллар башында Казанның тарихи өлешен реконструкцияләү барышында тарих-архит-ра мирасы булып саналган күп кенә мөһим истәлекләр югала. Шәһәрне 27 нче Бөтендөнья җәйге студентлар уеннары — «Универсиада-2013»кә әзерләгәндә төзелеш эшләренең зур программасы тормышка ашырыла. Универсиада авылы һәм 30 дан артык яңа спорт корылмалары: Спортның су төрләре сарае, Урта Кабан күлендә спортның ишкәкле төрләре үзәге, Теннис академиясе, Чирәмдәге хоккей үзәге, 45 мең тамашачы сыешлы «Казан-Арена» футбол стадионы һ.б. калкып чыга.

**Китап бастыру эше.** Казанда беренче нәшрият 1800 ел ахырында ачыла (к. *Азия басмаханәсе*). Казан губерна идарәсе (1804) һәм Казан ун-ты (1809) каршында басмаханәләр оештыру, Казанда Л.Шевиц, Р.Сәгыйтов, Ш.Яхин, К.А.Тиллиларның шәхси басмаханәләре, Г.М.Вечеславның басмаханәләре һ.б. оешу күпләп китап чыга башлауга этәргеч бирә (китаплар рус, татар, Россия халыклары телләре, шәрекъ телләрендә басыла). 19 йөзнең 1 нче яртысында нәшер ителгән китаплар саны буенча Казан Россиядә алдынгы урыннарның берсенә чыга (Мәскәү һәм С.-Петербургтан кала). 19 йөз ахырында анда 15 кә якын басмаханә исәпләнә, ел саен 1,5–2 млн. данә гомуми тираж б-н 140–180 исемдә татар китаплары дөнья күрә. Китапларның тематикасы төрле өлкәләргә карый: педагогика, медицина, хокук, тарих, табигыять фәннәре, ислам дине фикер иярәренең дингә, фәлсәфәгә һәм тарихка багышланган әсәрләре, сүзлекләр, үзөйрәткечләр. Болар барысы да халыкның укымышлылык дәрәҗәсен күтәрүгә йогынты ясый.

20 йөз башында басмаханәләр саны тагын да арта, бер үк вакытта китапларны нәшер итү, бастырып чыгару һәм сату ширкәтләре (*Кәримовлар басмаханәсе, ташбасмасы һәм хәреф коюю ширкәте, «Сабах», «Милләт», «Мәгариф»* һ.б.) барлыкка килә башлый. Татар китапларын бастыру эшендә *Харитонов И.Н. басмаханәсе, Перов И.С. ташбасмаханәсе, Домбровский Б.Л. басмаханәсе, Вараксин В.В. ташбасмаханәсе, Ермолаева И.В. һәм аның дәвамчылары басмаханәсе* һ.б. зур тырышлык күрсәтәләр. 1910 да Казанда 26 басмаханә исәпләнә, аларда гомуми тиражы 2586,8 мең данә тәшкил иткән 1 меңнән артык исемдәге китап (ш.и. 418 татар китабы) дөнья күрә. Россиядә нәшер ителгән татар китапларының 85% ка якыны Казанда басыла. Дөньяви эчтәлекле, ш.и. фәнни, уку-укыту һәм матур әдәбият китапларының (Р.Фәхретдин, Ә.Вәлиди, Г.Баттал, Г.Әхмәров, Х.Фәйзи, Ә.Максуди, Г.Баруди, М.Гафури, М.Фәйзи, Н.Думави һ.б.) өлеше арта. Тарих һәм ислам фәлсәфәсенә караган күпсанлы китаплар (М.Бигиев, З.Камали, З.Кадыйри, Габдулла Буби, Р.Фәхретдин һ.б. хезмәтләре) нәшер ителә. Татар китапларының бизәлеш һәм басылыш дәрәҗәсенең үсүе И.И.*Юзеев*, М.И.Идриси, Г.Камал эшчәнлекләре б-н бәйле.

Окт. рев-циясеннән соң китап бастыру эше тулысынча дәүләт һәм КПСС органнары күзәтчелегенә алына. Басмаханәләр национализацияләнә һәм эреләндерелә. 1919 да нәшрият эшчәнлеген җайга салу, китаплар чыгару һәм сату өчен, Госиздатның Казан бүлеге оештырыла. 1920 еллар ахырына кадәр эре дәүләт заказларын үтәүче һәм еш кына китап сәүдәсе б-н шөгыльләнүче хосусый һәм кооператив пр-тиеләр дә эшләүләрен дәвам итә. Кубесенчә сәяси, уку-укыту һәм фәнни-популяр әдәбият басыла. Китапларның яртысыннан артыгы татар телендә чыга. ТАССРның *Китап палатасы* оешканнан бирле (1926) чыккан китапларны теркәү гамәлгә ашырыла. 1920 еллар ахырына үзәкләштерү шартларында хосусый һәм ведомство нәшриятлары эшләүдән туктый. Мәскәүдә «Нәшрият» кооператив нәшрияты, СССР халыклары Үзәк нәшриятының Татарстан бүлеге, Донецк, Свердловск, Новосибирск һ.б. шәһәрләрдәге өлкә нәшриятларының татар секцияләре ябыла. 1930 еллар башында Татиздат татар телендәге әдәбият чыгаручы бердәнбер нәшрият була. Аның эш күләме күрсәткечләре үсә, басылган китаплар исемлегенең саны арта (1929 да — 182, 1930 да — 266, 1931 дә — 568, 1932 дә 851 исемдә китап чыга). Китап басу процессларының тупланышы эшне оештыруның яңа формаларын, югары җитештерүчәнлекле полиграфия машиналары куллануны таләп итә, әмма Татиздатта редакция процесслары гына түгел, китап чыгару технологиясе дә 19 йөз дәрәҗәсендә кала. Хәрефләр кульязма текстлардан (гарәп хәрефле язу машиналары булмый) һәм, гарәп алфавитына карата Европа линотипларын куллану мөмкинлеге булмаганга, кул б-н җыела. Татар язуы реформасы — латин шрифтына күчү нәтиҗәсендә (1932) «Яңалиф» язу машинасын куллану мөмкинлеге барлыкка килә, текстлар җыйганда хезмәт җитештерүчәнлеге арта (линотиплар файдаланыла башлый), китапларның техник бизәлешендә яңа мөмкинлекләр ачыла. ТАССР ЮС Президиумының 1939 ел 5 май Указы б-н татар язуы латинлашкан алфавиттан рус графикасы нигезендәге алфавитка күчерелә. Татар халкының язу реформасы барышында аның мәдәниятенә сизелерлек зыян килә, үсеп килүче буын — гарәп, аннары латин графикасы нигезендә тудырылган язма мәдәни байлыклар б-н танышу мөмкинлеген югалта. 1936 да китап сату ТАССР Сәүдә халык комис-ты аша гамәлгә ашырыла башлый. Бөек Ватан сугышы елларында басма продукциянең күләме кими. Басмаларның тематикасы үзгәрә, китаплар аз чыга башлый. Матди ресурслар кискен кимү һәм эшчеләр азаю шартларында Татгосиздат (к. *Татарстан китап нәшрияты*) фронт һәм тылны китап, брошюра, листовка, плакатлар б-н тәэмин итү өчен барысын да эшли. Респ-ка полиграфистлары армия басмаханәләрен җиһазлау һәм туплауда зур булышлык күрсәтә. Сугыш елларында татар телендә 16 хәрби газета чыга. 1940–50 елларда китаплар исемлегендә милли әдәбият әсәрләренең өлеше зур булмый. 1953 тә Татгосиздат гомуми күләме 1475 табак булган 183 исемдәге китап чыгара (1300 табактан артыгragы — кабат басылган һәм тәрҗемә китаплар). Китап сату Таткниготорг һәм Татпотребкооперация аша алып барыла. «Җепшеклек» елларында (1950 елларның 2 нче яртысы — 1960 еллар уртасы) китапларның тематикасы киңәя. 1963 тә 1006 исемдәге китап басыла, аларның 593 е — татар телендә. М.Әмир, Г.Бәширов, Н.Исәнбәт, Ф.Хөсни, И.Гази, Р.Ишморат, Г.Әпсәләмов, Ә.Еники, Н.Дәүли, К.Тинчурин, Г.Ибраһимов, Х.Туфан һ.б.ның әсәрләре дөнья күрә. 1960–70 елларда нәшрият гомуми тиражы 4 млн. 283 мең данә булган (337 исемдә) әдәби әсәрләр бастыра. Алдагы бишьеллыкта Татарстан китап нәшриятының әдәби әсәрләр бастыру күрсәткече ел саен кимүгә таба бара. 1971–75 тә чыккан китапларның гомуми күләме нибары 2821 табак тәшкил итә (269 исемдә).

1990 елларда дәүләт нәшриятларын хосусыйлаштыру, хосусый фирмалар оештыру башлана. Яңа эре китап пр-тиеләре: Татарстан газета-журналлар нәшрияты (к. «*Идел-Пресс*» *Полиграфия-нәшрият комплексы*), «*Рухият*» оеша. 1991–2010 елларда мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен татар телендә дәреслекләр чыгаручы «Мәгариф» нәшрияты эшли. Алар б-н беррәттән хәзерге вакытта «Раннур», «Заман», «*Яңалиф*», «Иман», «Медицина», «Мәгариф-Вакыт» һ.б. нәшриятлар эшләп килә. «Идегәй» эпосы, Ш.Мәрҗани, Г.Гобәйдуллин, Г.Исхакый әсәрләре, Һ.Атласи, Р.Фәхретдин хезмәтләре басыла. 2014 тә ТРның әйдәп баручы нәшриятлары тарафыннан гомуми тиражы 1648200 данә булган 1397 исемдәге китап һәм брошюра чыгарыла.

*Әд.:* Гафуров В.З., Мифтахов З.З. Развитие полиграфии и печати в Татарии. К., 1977; Каримуллин А.Г. Татарское государственное издательство и татарская книга России (1917–1932). К., 1999.

**Китапханәләр.** Төбәк терр-ясендә беренче китапханәләр Идел буе Болгар дәүләтендә барлыкка килә. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасының 13 йөздәге төп нөсхәләреннән 16–18 йөзләрдә күчереп язылган кульязмалар сакланган. Казан ханлыгында шәхси, сарай, уку йортлары (мәдрәсә һәм мәктәпләр каршында) китапханәләре эшләп

килә. Мәчетләр каршындагы китап тупланмаларында 14–16 йөзләр кульязма китапларының күп булуы билгеле. Казан ханлыгы яулангannan соң, әлеге китапханәләрнең күбесе юкка чыгарыла. 16–17 йөзнең 2 нче яртысында монастырь һәм чиркәү китапханәләре, скрипторийлар оеша башлый. Төбәктә китапханәләрнең алга таба үсеше 18 йөздә цифирь (1718), славян-латин (1723) мәктәпләре, Казан руханилар семинариясе (1723), «Буби» мәдрәсәсе (1781) ачылу б-н бәйле. Әлеге чорның мәдәният эшлеклеләре – М.И.Верёвкин, Ю.И. фон Каниц, И.И.Панаев, В.И.Полянский, С.А.Москотильников, Г.П.Каменев, С.Х. һәм И.И.Хәлфиннәр, Н.М. һәм Л.Н.Ибраһимовлар, М.Мәхмүдов һ.б.ның бай шәхси китапханәләре булуы мәгълүм. 19 йөздә әре уку йортлары – Казан ун-ты (1804), Казан руханилар академиясе (1842), «Мәрҗания» мәдрәсәсе (1870), «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе (1882) һ.б.ның китапханәләре оеша. 1861 гә Казан губернасында 42 китапханә була, аларда 148 мең том китап саклана. 1860–70 елларда Казан ун-ты гыйльми җәмгыятьләренең (табибләр, физик-матем., табигыятьчеләр, археол., тарих һәм этнография җәмгыятьләренең һ.б.) китапханәләре оеша. 1865 тә Казанда – беренче җәмәгать китапханәсе (хәзерге *Татарстан Республикасының Милли китапханәсе*), 1875 тә – Чистай шәһәре Казан губернасында беренче земство китапханәсе барлыкка килә; 1880–90 елларда аларны оештыру шәһәр һәм земство үзидарә органнары башлангычы б-н эшләнә. 1883 тә китапханәләр – Зөя, Спас, 1887 дә – Лаеш, Тәтеш, 1895 тә – Минзәлә, 1896 да Алабуга шәһәрләрендә ачыла. 1892 дә Казан губернасында 12 җәмәгать китапханәсе була, анда 11402 исемдә китап (32280 том), 20349 китап укучы исәпләнә, китапханәләрнең 11 е өязләрдә (16048 томда, 4322 исемдәге басма, 837 китап укучы) эшли. 1900 гә төбәктә 13 җәмәгать китапханәсе була. 1890 еллардан Казан губернасында халык китапханәләре ачыла башлый. 1909 да Спас өязендә 32 шундый китапханә оеша, Тәтеш өязендә – 23, Чистай өязендә – 13, Зөя өязендә – 12, Мамадыш өязендә – 6 һ.б.; аларның күбесе өяз земстволарына, калганнары иҗтимагый оешмаларга карый. Казанда түләүсез китапханә-уку бүлмәләре эшли: Казан дары з-ды каршында (1896 дан), Алафузов ф-касы каршында (1900 дән), Гоголь исем. (1902 дән) һәм Некрасов исем. (1903 тән). 20 йөз башыннан татар җәмәгать китапханәләре ачыла: «Көтебханәи исламия» («Исламия китапханәсе», 1906), Алафузов ф-касында – татар эшчеләре (1906), Шәрекъ клубы (1908) китапханәләре, Г.Шәрәф китапханәсе һәм уку бүлмәсе (1916) һ.б. 1910 елларда Казан хәрби гарнизоны частьларында мөселман уку бүлмәләре оештырыла.

Окт. рев-циясеннән соң китапханә эше халык мәдәниятен күтәрү буенча гомумдәүләт чараларының бер өлеше була. Респ-каның күпмилләтле халкына хезмәт күрсәтү өчен, яңа массакүләм китапханәләр челтәре киңәйтелә (совет хакимиятенең беренче елларында 218 китапханә һәм уку залы оештырыла, ш.и. 138 е татарлар өчен). 1919 да – балалар китапханәсе, 1920 дә – ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-ты китапханәсе (хәзер Респ-ка мед. китапханә-мәгълүмат үзәге), 1933 тә *Республика махсус сукырлар китапханәсе* ачыла. 1920 еллар ахырыннан – профсоюз (1930 га 549 профсоюз оешмасыннан 400 енең китапханәсе була), партия китапханәләре ачыла. Бөек Ватан сугышы алдыннан респ-када 2251 массакүләм китапханә эшли, сугыш елларында аларның саны кими. 1945 тә СССР ФАнең Казан ф-лы китапханәсе ачыла. 1960 та ТАССР Мәдәният министрлыгы карамагында 2379 китапханә исәпләнә. 1975–80 дә массакүләм китапханәләр үзәкләштерелгән китапханә системасына (ҮКС) берләштерелә.



ТР Милли китапханәсе. Төп бина.

1977 дә Респ-ка яшүсмерләр китапханәсе ачыла. 1980 дә Татарстанда – 1745, 1990 да – 1799, 2000 дә – 1649 массакүләм китапханә исәпләнә (аларның барлык фонды 25 млн. га якын саклау берәмлеген тәшкил итә). Профсоюз китапханәләре 24 ҮКСна берләштерелә, аларның саны 159 га кала; партия китапханәләре 1990 да бетерелә.

Респ-ка китапханәләрендә басылган яки басылмаган төрле документлар, Россия халыклары, БДБ илләре, Европа һәм Шәрекъ телләрендә язылган басмалар, ноталы, картографик материаллар; мәгълүмат-эзләү системаларында чагылдырылган электрон, аудио һәм визуаль документлар саклана. Китапханәләрдә язучылар иҗатына багышланган укучылар конференцияләре, язучылар б-н очрашулар, китап тәкъдим итү, диспут, дискуссияләр уздырыла. 1990 еллар башыннан күп кенә массакүләм китапханәләрдә татарларның мәдәни мирасын саклау һәм пропагандалау буенча актив эш алып баручы туган якны өйрәнү һәм татар әдәбияты бүлекләре эшләп килә. Соңгы елларда китапханәләрнең социаль функцияләре сизелерлек үсә. Алар ветераннар советлары, инвалидлар җәмгыятьләре б-н хезмәттәшлек итәләр; өлкән яшьтәге китап укучылар һәм инвалидлар өчен мәдәният эшлеклеләре б-н очрашулар, ял кичәләре уздырыла. Заманча мәгълүмати технологияләр кертелә, эшнең яңа формалары тәкъдим ителә: виртуаль күргәзмәләр, интернет-дәресләр, укучылар өчен интерактив конкурслар һ.б. 2007–08 дә ТР телекоммуникацияләренең дәүләт бердәм челтәренә 100 муниципаль китапханә тоташтырыла, кулланучылар Интернет челтәренең мәдәни һәм белем бирә торган мәгълүмати ресурсларына түләүсез керү мөмкинлеге ала. «Консультант Плюс» һәм «Гарант» мәгълүмати-хокукый эзләү системалары актив кулланыла.

Китапханәләрдә эшләү өчен белгечләр 1935 тән – Алабуга китапханә техникумында (хәзерге Алабуга мәдәният уч-щесе), 1969 дан Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тында әзерләнә. Татарстанның иң зур китапханәләре булып ТР Милли китапханәсе һәм *Казан университетының фәнни китапханәсе* (Н.И.Лобачевский исем.) (РФнең иң борынгы фәнни китапханәләреннән берсе, фондының күләме буенча университет китапханәләре арасында өченче) санала. Бөтенроссия китапханәләрен исәпкә алу нәтиҗәләре буенча 2010 да респ-када ТРның төрле министрлыклары, ведомстволары, муниципаль хакимият органнары, оешмалар, пр-тиеләр карамагында эшләп килгән 3300 дән артык китапханә исәпләнә. 2014 тә ТР Мәдәният министрлыгы карамагында – 1550 китапханә (4 респ-ка китапханәсе, калганнары – муниципаль китапханәләр); алар респ-ка халкының 38,7% ына хезмәт күрсәтә; китап фонды – 23535680 саклау берәмлеге. Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагында – 1408 китапханә, Сәламәтлек саклау министрлыгында – 21, Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгында – 97, профсоюз оешмаларында – 13, ТР ФА Фәнни-тикшеренү ин-тларында – 4, РФА КГҮдә – 1, федераль буйсынудагы югары уку йортларында – 20 китапханә. Коммерциячел югары уку йортлары китапханәләре эшләп килә.

1980 елларның 2 нче яртысында иҗтимагый-сәяси тормыштагы кискен үзгәрешләр китапханә хәленә тискәре йогынты ясый. Финанслау кимү аркасында китапханәләр фондлар туплауда кыенлыклар кичерә. Һәркем йөри алырлык дәүләт китапханәләрен җирле үзидарә органнары карамагына тапшыру аларның саны кыскаруга китерә (2007 дә – 1625, 2014 тә – 1550 китапханә).

**Музейлар**. Казан губернасында беренче музейлар 19 йөз башында Казан ун-ты каршында ачыла. 19 йөз ахырында – 20 йөз башында Казанда шәһәр музейлары ачыла башлый. Уку йортларында (руханилар академиясендә, сәнгать мәктәбендә, Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында), оешмалар каршында (Казан епархиясенең тарих-археол. җәмгыяте мирасханәсе, Казан икътисад җәмгыятенең умартачылык музее) музейлар эшләп килә. *Казан губерна земствосының вак сәнәгать һәм һөнәри белем бирү үзәк музее* (1981) һәм Казан дворяннары җыены мирасханәсе оештырыла. 1895 елда Шәһәр фәнни-сәнәгать музее (соңрак – ТАССР Үзәк музее, хәзер – *Татарстан Республикасының Милли музее*). 1920 елларда респ-када музей эше үсешендә һәм музей фонды формалашуда ТАССР Мәгариф халык комис-тының Музейлар эшләре һәм һәйкәлләрне саклау бүлеге зур роль уйный (аерым затлардан, дини оешмалардан тартып алынган мөлкәттән тарих-сәнгать байлыкларын сайлап исәпкә алу эшен башкара һәм аларны музейларга тапшыра). 1920 еллар башында төбәкне өйрәнү гыйлеменең үсеше б-н мәдәни-агарту һәм фәнни эштә музей-








1. ТР Милли музее; 2. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее. Төп бина; 3. «Казан» милли мәдәният үзәге; 4. «Хәзинә» милли сәнгать галереясы (барысы да Казанда); 5. Чистай өяз каласы музее; 6. Алабуга шәһәре тарихы музее.

ларның роле шактый кечәя. 1920–24 тә Казанда *«Казанский музейный вестник»* һәм «Записки Тетюшского музея» ж-ллары нәшер ителә. Аларда музей эшенең актуаль мәсьәләләренә зур игътибар бирелә. 1920 еллар ахырыннан илдә төбәкне өйрәнү эше сүлпәнәя башлый: кантон һәм район музейлары ябыла, ТАССР Үзәк музееның фәнни-тикшеренү һәм туплау эшчәнлеге чикләнә. Шул ук вакытта респ-када мемориаль һәм тарихи-биографик экспозицияле музейлар ачыла: *Ленин В.И. музей-йорты* (1937), Ленино-Кокушкино авылында В.И.Ленин музее (1939; к. *«Ленино-Кокушкино» музей-саклаулыгы*), *Горький А.М. әдәби-мемориаль музее* (1940), *Камал Шәриф музей-фатиры* (1950). Яңа музейлар үсеше 1950 еллар уртасыннан яңадан башлана. 1958 дә ТАССР Дәүләт музее сәнгать коллекцияләре нигезендә Сынлы сәнгать музее, 1956–70 тә *мемориаль музейлар* (Алабуга шәһәрендә *Шишкин И.И. музей-йорты*, Бөгелмә шәһәрендә *Гашек Ярослав әдәби-мемориаль музее*) оеша. 1980–90 елларда төбәкне өйрәнүчеләр башлангычы һәм җирле идарә ярдәме б-н ТАССР Берләштерелгән дәүләт музее җирлегендә музей эшенең үзәкләштерелүе нәтиҗәсендә адм. үзәкләрдә, шәһәр һәм авылларда яңа төбәк һәм мемориаль музейлар оештырыла (*Җәлил Муса музей-фатиры*, Казанда *Тукай Габдулла әдәби музее*, *Салих Сәйдәшев музее*, *Боратынский Е.А. әдәби музее*, *Урманче Бакый музее*, Арча р-ны Яңа Кырлай авылында *Тукай Габдулла музей-комплексы* һ.б.). Югары уку йортларында, А.Е.Арбузов исем. Органик һәм физик химия ин-ты каршында (*Арбузовлар А.Е. һәм Б.А. музей-йорты*) музейлар эшләп килә. Казан ун-ты (*Казан химия мәктәбе музее*, геол., ботаника, зоол., археол., этнография музейлары), Казан мед. ун-ты (*Анатомия театры, Патология-анатомия музее*) музей фондлары аеруча бай. Ведомстволар каршында музейлар оештырыла (ТР Элемтә министрлыгы каршында Элемтә тарихы музее, Татарстан милициясе музее, Татар акад. театрында Театр сәнгате музее, Казан Зур драма театры, Татар опера һәм балет театры музейлары). Музейлаштырылырга тиешле объектларны һәм аларның мохитен сайлауның яңа критерийлары эшләнә. Шуңа бәйле рәвештә музей-утарлар, *музей-саклаулыклар* оеша башлый. *«Казан Кремле»* тарих-архит-ра һәм сәнгать музей-саклаулыгы Казанның иң зур музей үзәгенә әверелә. Музей-саклаулык терр-ясендә зур экспозицияләр оештырыла: «Татар халкының дәүләтчелеге һәм Татарстан тарихы» музее, *«Эрмитаж-Казан»* үзәге, «Хәзинә» милли сәнгать галереясы, Татарстанның табигыять тарихы музее, Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы. Археология музее ачуга әзерлек алып барыла. Музейлар эшендә концерт программалары, шоу, фестивальләр, осталык дәресләре һ.б. кебек «музейлар эшчәнлегенә карамаган» сәнгать төрләре зур урын били. ТРда музей эше үсешенә Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек зур этәргеч була. ТР Милли музее бинасы төзекләндерелә һәм реконструкцияләнә, музей практикасының яңа казанышларына нигезләнеп, экспозицияләр яңадан төзелә. *Алабуга тарих-архитектура һәм сәнгать, Иске Казан тарих-мәдәният һәм табигать музей-саклаулыклары* оештырыла.

Респ-ка музейлары фәнни-тикшеренү, агарту, туплау һәм реставрацияләү эшләре алып бара. Горький, Шаляпин, Каменев, Тукай, Сәйдәшев укулары, М.Җәлил истәлегенә багышланган көн һ.б. чаралар уздырыла. Илнең зур музейлары: Рус музее, Третьяков галереясы, Россия Сәнгать академиясе музее, Эрмитаж б-н бергәләп экспозиция-күргәзмә проектлары гамәлгә ашырыла. Фәнни мәкаләләр җыентыклары, монографияләр, каталоглар, 1995 тән «ТР Милли музееның еллык басмасы» («Ежегодник Национального музея РТ») нәшер ителә. Музей эше үсешенә В.М.Дьяконов, Н.И.Воробьёв, Е.Г.Бушканец, М.Н.Елизарова, Ю.И.Петров, Л.Г.Вәлиева, Г.С.Муханов, С.В.Писарева, Г.А.Могильникова, М.Т.Низамиев, Д.Б.Баһаветдинова, Р.Г.Гарифҗанова һ.б. зур өлеш кертәләр. 2013 тә Татарстан музейларында 2 млн. 943 мең кеше була; 49502 экскурсия уздырыла, 1643 күргәзмә оештырыла. 2014 елга ТРда 129 музей оешмасы: 32 структур бүлекчәсе булган 13 дәүләт музее һәм музей-саклаулыгы, 35 ф-лы булган 49 муниципаль музей эшләп килә.

Музейлар өчен белгечләр Казан (Идел буе) федераль ун-тының тарих ин-тында (2003 тән), Казан мәдәният ин-тында (2004 тән) әзерләнә.

*Әд.:* Синицына К.Р. Полвека музеев Казани и Татарии: Очерки истории 1917–1967 годов. К., 2002; Все музеи Казани: Справ.-путеводитель. К., 2004.

## VIII. МАССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫ (ММЧ)

Казанда төбәкнең иҗтимагый һәм мәдәни тормышында мөһим роль уйнаган вакытлы матбугат барлыкка килү 19 йөз башына карый. 1808 елда Казан ун-ты профессоры И.И.Запольский *«Казанские известия»* г-тасының рус һәм татар телләрендәге проектын әзерли. 1809 да ул газетаның рус телендәге басмасын нәшер итүгә рөхсәт ала. 1811–20 дә чыккан «Казанские известия» Россия провинцияләрендә даими рәвештә нәшер ителгән тәүге газеталарның берсе була. Аның дәвамчысы — шәһәр матбугаты тарихындагы иң беренче журнал *«Казанский вестник»* (1821–32). Наширләре һәм авторлары — күренекле язучылар һәм галимнәр, ш.и. Н.С.Арцыбышев, В.Я.Баженов, Н.И.Лобачевский, М.К.Казимбәк, О.М.Ковалевский, М.С.Рыбушкин, И.М.Симонов, К.Ф.Фукс һ.б. Казанда «Заволжский муравей» хосусый жур-

налы зур казанышка ирешә. Журнал мәкаләләре тематика киңлеге б-н аерылып тора: басмада төбәк тарихы яктыртыла, география, статистика буенча материаллар урын ала, җирле җәмгатьчелек өчен мөһим булган сорауларны куюы омтылышы күзәтелә. Төбәктәге тарих юнәлешендәге һәм фәнни матбаганың барлыкка килүе Казан ун-ты б-н бәйле (1834 тән *«Учёные записки Казанского университета»*дан башлап үзенең елъязмасын алып бара, басмаларның башлап җибәрүчесе — Н.И.Лобачевский). «Учёные записки...»ның төрле еллардагы мөхәррирләре — танылган галимнәр Н.Н.Булич, Н.И.Ильинский, Н.А.Осокин, А.М.Осипов; басмада Н.Н.Зинин, А.М.Бутлеров, А.Е.Арбузов, Е.К.Завойский, С.А.Альтшулер, А.Н.Пудовик һ.б.ның мәкаләләре дөнья күрә. 1838 дән Казанда *«Казанские губернские ведомости»* г-тасы рәсми газета буларак чыгарыла һәм 19 йөзнең 2 нче яртысына кадәр Казан губернасында бердәнбер вакытлы матбугат басмасы була.

19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында социаль-икътисади үсешнең тизләнеш алуы, иҗтимагый-сәяси тормышның катлаулануы газета һәм журналларның киң тармаклы челтәре барлыкка килүгә этәргеч бирә. Казан һәм Идел-Кама төбәге иҗтимагый тормышына багышланган мәкаләләрне үз эченә алган басмалар — *«Справочный листок города Казани»*, *«Казанский биржевой листок»*, *«Камско-Волжская газета»*, *«Городской листок»*, *«Казанские новости»*, *«Волжско-Камское слово»*, *«Камско-Волжский край»*. «Волжский вестник» г-тасы губерна мәдәни тормышының җитди казанышы була. Материалларының иҗтимагый әһәмияте һәм тирәнлеге, демократик интеллигенциянең күренекле вәкилләре хезмәттәшлеге бәрабәренә ул 19 йөз ахырында Россиянең иң яхшы газеталарыннан берсенә әверелә. 1900 дә Казанда 21 вакытлы матбугат басмасы исәпләнә.

Хакимият каршылыгы аркасында татар телендәге матбугат барлыкка килү бары тик 1905–07 елгы рев-ция вакыйгалары барышында гына мөмкин була. Моңа кадәр гектографта басылган легаль булмаган «Иттифак» (1902–1905) һәм «Хөррият» (1905) г-талары гына чыга. 1905 нең 7 октябрендә Казан шәһәр думасы гласные С.Алкин *«Казан мөхбире»* (1905–11) г-тасын бастыруга рөхсәт ала, аның беренче саны 1905 нең 29 октябрендә дөнья күрә. 1906 ның гыйнвар уртасыннан *«Йолдыз»*, 1906 ның февраленнән *«Азат»* г-талары басыла башлый. Казан тарихында иң беренче татар журналы булып *«әд-Дин вә әл-әдәб»* (1900) тора. Рев-циягә кадәрге чорда чыккан иң абруйлы басмалар — «Йолдыз» (1906–18), *«Бәянелхак»* (1906–14), *«Кояш»* (1912–18), *«Тормыш»* (1913–18), «Азат» (1906), *«Таң йолдызы»* (1906), *«Безнең таваыш»* (1917–18), *«Корылтай»* (1917–18). *«Аң»* (1912–18), *«Тәрбия»* (1908), *«Мәктәп»* (1913–14) ж-ллары үз сәхифәләрендә демократик идеяләр үткәрәләр. Бу чорда беренче хатын-кызлар журналы — *«Сөембикә»* (1913–18) дөнья күрә. Казан вакытлы матбугатында *«Яшен»* (1908–09) һәм *«Ялт-Йолт»* (1910–18) сатирик ж-ллары аерым урын алып тора. Казандагы вакытлы матбугат тарихы татар интеллигенциясенең күренекле вәкилләре Ф.Әмирхан, Г.Тукай, Г.Камал, Г.Исхакый, Ш.Әхмәров, Ә.Максуди, Ф.Туктаров һ.б. исемнәре б-н бәйле. Алар үз язмаларында татар халкы язмышы, аның милли яңарышы проблемаларын, мәдәният һәм мәгариф үсеше мәсьәләләрен күтәрәләр, халыкларның тигез хокуклылыгы идеяләрен пропагандалыйлар. Барлык татар басмаларында диярлек татар әдәбияты һәм әдәби теле үсеше мәсьәләләре карала, оригинал һәм тәрҗемә әсәрләр басыла.

Совет хакимияте урнашу б-н, вакытлы матбугат системасы шактый үзгәрешләр кичерә: совет матбугаты органнары барлыкка килә. 1917 нең 29 октябрендә Казанда «Знамя революции» г-тасының (Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларының Казан советы органы) беренче саны чыга, 1918 нең 12 мартында — Казан советы каршындагы Мөселман комис-ты органы — татар телендәге беренче совет *«Эш»* г-тасы басыла. Татар телендәге беренче совет газеталары исәбенә *«Кызыл байрак»*, *«Кызыл Армия»* һ.б. керә. Окт. рев-циясеннән соң партия-совет газеталары Казан губернасының барлык өязләрендә диярлек чыга башлый, ш.и. чуаш (*«Канаш»*, *«Хĕрле ялав»*), мари («Йошкар кәче», *«Тор»*, *«Ужара»*) һәм удмурт (*«Гудыри»*) телләрендә дә газеталар басыла. 1918–20 дә Казанда крәстияннәр өчен махсус *«Бедняк»* һәм *«Деревенские думы»*, яшьләр өчен «Клич юного коммунара», *«Кызыл яшьләр»* г-талары нәшер ителә. 1917 нең 28 октябрендә «Матбугат турында декрет» кабул ителгәннән соң, большевистик булмаган газеталар җирле хакимият тарафыннан ябыла башлый. Гражданнар сугышы чорында Татарстан терр-ясендә үзара көрәшүче якларның *армия газеталары* күпләп нәшер ителә.

ТАССР оештырылгач, совет вакытлы матбугаты формалаша башлый. 1920 еллар башында хуҗалыкны торгызуның авыр шартларында журнал тибындагы 20 дән артык басма чыга: *«Казанский музейный вестник»*, *«Вестник просвещения ТАССР»*, *«Сельское и лесное хозяйство Татарстана»*, *«На страже законности и порядка»* һ.б. 1920 нең 1 декабрендә РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты *«Вестник Татарского областного комитета РКП(б)»* ж-лын бастыра башлый, соңыннан ул *«Коммунист Татарии»* дип үзгәртелә. Журнал рус һәм татар телләрендә чыга, совет чорында ул әйдәп баручы фәнни-сәяси, теоретик басма ролен үти. Керәшен татарлар өчен 1920 елларда *«Белемнек»* һәм *«Киңәш»* ж-ллары чыга. 1925 тә профсоюзлар ж-лы «Пролетарий Татарстана» чыга, 1928 дән ТАССР ҮБКның *«Татарстан Советлары»* ж-лы дөнья күрә. 1920–30 елларда яңа фәнни журналлар арасында *«Татарстан»*, *«Социалистическое хозяйство Татарстана»*, *«Вестник Казанского института научной организации труда»*, *«Вестник Научного общества татароведения»*, *«Записки Центрального архива Татарской Социалистической Советской Республики»*, *«Известия Казанского института сельского хозяйства и лесоводства»* һ.б. чыга. 1930 да ТАССРда *шәһәр, район-шәһәр, район газеталары*, ш.у. *күптиражлы газеталарның* киңтармаклы челтәре оеша. Рәсми басмалар б-н беррәттән крәстиян, яшьләр, балалар газеталары һәм журналлары басыла. Сугыштан соңгы чорда ТАССР матбугаты нигезен «Социалистик Татарстан», «Советская Татария» респ-ка басмалары, «Татарстан яшьләре», «Комсомолец Татарии», яшьләр г-талары, «Яшь ленинчы» балалар г-тасы тәшкил итә. Татар әдәбияты һәм публицистикасы үсешендә бөтен совет чоры дәвамында *«Казан утлары»* ж-лы мөһим урын алып тора. Рус телендә «Литературная Казань» һәм *«Литературный Татарстан»* альманахлары басыла.

1980–90 елларда ил тормышындагы тамырдан үзгәрешләр вакытлы матбугат структурасындагы үзгәрешләргә китерә. Сугыштан соңгы чорда беренче тапкыр татар телендә яшьләр өчен әдәби *«Идел»* ж-лы (1989 дан) чыга башлый. 1990 да «Казань», «Мирас» ж-ллары, фәнни учреждениеләр башлангычы б-н *«Научный Татарстан»*, *«Неврологический*




*вестник имени В.М.Бехтерева», «Фән һәм мәктәп — Наука и школа», «Вертеброневрология»* һ.б. ж-ллар нәшер ителә башлый. Иҗтимагый-сәяси оешма басмалары (*«Известия ТОЦ», «Независимость», «Слово коммуниста», «Суверенитет»* һ.б.) һәм хосусый газеталар барлыкка килә. Вакытлы матбугатның тематикасы киңәя: эшлекле даирәләр өчен газета басыла (*«Время и деньги»*), реклама басмалары («Казанская ярмарка», «Из рук в руки», «Ва-банкъ» һ.б.), дини газеталар (*«Вера», «Иман»* һ.б.) дөнья күрә. Татар диаспорасы өчен татар һәм рус телләрендә *«Татар иле — Татарские края»* г-тасы нәшер ителә.






















Хәзерге вакытта ТРда әйдәп баручы басмалар булып *«Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан», «Мәдәни җомга», «Вечерняя Казань», «Татарстан яшьләре»* г-талары тора. Казанда *«Шәһри Казан», «Казанские ведомости»* г-талары абруй казана. Иң эре ж-ллар — *«Татарстан», «Казан утлары», «Казань»*, «Безнең мирас», «Идел», «Научный Татарстан», *«Сабантуй», «Сөембикә», «Чаян», «Ялкын»*. 1990 да ТРның зур шәһәрләрендә — Әлмәт, Яшел Үзән, Чаллы, Түбән Камада басмалар даирәсе киңәя. Күп кенә район газеталары яңа исемдә чыга башлый, аларның эчтәлекләре яхшыра. 2016 ел башына ТРда редакцияләре респ-ка терр-ясендә урнашкан 1193 массакүләм мәгълүмат чарасы теркәлә, ш.и. 780 вакытлы басма, 144 телеканал һәм телетапшырулар, 155 радиоканал һәм радиотапшырулар, 96 электрон вакытлы басма, 18 мәгълүмат агентлыгы. Татар телендә 186 газета һәм журнал, чуаш телендә 5 газета, удмурт телендә 1 газета чыга.

ТРның медиа киңлегендә 15 мәгълүмат агентлыгы: Россия төбәк агентлыклары арасында лидерлар рәтендәге «Татар-информ», Дәүләт мәгълүмат агентлыгы «Зелёный Дол», «Новый Зай» һәм башка 137 электрон вакытлы басма эшләп килә. ММЧ өлкәсендә дәүләт сәясәтен *«Татмедиа»* респ-ка матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы үткәрә, Татарстан ММЧ порталын (tatmedia.com) булдыра, анда респ-ка, район һәм шәһәр ММЧ үз материалларын Интернетта урнаштыра.



Казан телеүзәгенең телевизион вышкасы.

Татарстанның *радиотапшырулар* тарихы 1918 нең 20 мартында Казан кабул итү радиостанциясен эшләтеп җибәрүдән башлана. 1918–19 да Тәтеш, Спас, Бөгелмә, Минзәлә, Чистай шәһәрләрендә кабул итү станцияләре сафка бастырыла. 1919 да Кызыл Армиянең *Радиотелеграф оешмаларының Казан базасы* оеша. 1921 нең маенда Казанда (Россиядә беренче булып) репродуктор куела. Татарстан радиосының татар һәм рус телләрендәге беренче тапшырулары 1927 нең 7 ноябрендә чыга, 1933 тән чуаш телендә дә радиотапшырулар башлана. 2014тә ТР терр-ясендә 22 радиостанция теркәлгән, шулардан 7 радиостанция тапшыруларны татар телендә алып бара. «Болгар радиосы» радиостанциясе үзенең программалаштыруы нигезендә ТР терр-ясендә тәүлек дәвамында 37 ретранслятор аша һәм Интернет челтәрендә ике дәүләт телендә тапшырулар алып бара; аларны иярчен аша Россиянең Европа өлешендә, Көнчыгыш Европа илләрендә кабул итәргә мөмкин, аның потенциаль аудиториясен 4 млн.нан артык тыңлаучы тәшкил итә. *«Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе* (ТНВ) РФнең бөтен терр-ясендә тәүлек буе эшли, аның сигналы ш.у. Белоруссия, Украина, Болгария, Румыния, Латвия, Литва, Финляндия, Казакъстан терр-яләрендә дә кабул ителә (төрле яшьтәге тыңлаучылар өчен татар телендәге мәгълүмати, аналитик, муз. һәм әдәби программалар трансляцияләнә: «Халкым минем» һ.б.). «Татарстан» Дәүләт телерадиокомпаниясе (ДТРК)» Федераль дәүләт унитар пр-тиесе ф-лы «Татарстан дулкынында» көндәлек программасын РФнең үзәк һәм Европа өлешендә, Себердә трансляцияли. «Татарстан» ДТРК ф-лының милли тапшырулары хезмәте тарафыннан татар телендә әдәби-музыкаль һәм дини-агарту радиопрограммалары әзерләнә.

1959 да Татарстанда даими *телевидение тапшырулары* башлана. «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясенең «Татарстан — Яңа гасыр» (ТНВ) телеканалы — арада иң зурысы. Ул Татарстан халыкларының рухи, мәдәни, танып белү һәм ял ихтыяҗларын канәгатьләндерүне төп максаты итеп куя. Әйдәп баручы телекомпанияләрнең тагын берсе — телетапшырулар өлкәсендә бай традицияләргә ия булган *«Татарстан» Дәүләт телерадиотапшырулар компаниясе*. Казанда телеүзәк бар, 7 җирле телеканал, ш.и. ТНВ, *«Эфир»*, «Казань», «Мәйдан» һ.б., ш.у. 4 федераль каналның («Беренче канал» ААҖ, БДТРК, «Петербург» ТРК ААҖ (5нче канал), «Матч ТВ») хәбәрчелек пунктлары эшли. 2000 еллар башыннан респ-када кабельле һәм цифрлы тапшырулар актив үсештә, шулар ярдәмендә халык РФнең башка өлкәләре тапшыруларын гына түгел, чит ил телекомпанияләре тапшыруларын да карый ала.

*Әд.:* П е т р о в с к и й Н.М. По поводу столетия Казанской периодической печати // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1911. Т. 17, вып. 3; Н у р у л л и н а Р.М. Становление партийно-советской печати на татарском языке (1917–1925). К., 1978; Н а с ы р о в Т.М. Октябрь и печать Татарии. К., 1975; Ф а с а х о в К.М. С жизнью в ногу (Периодическая печать Татарии в восстановительный период). К., 1979; Е р ш о в А.Н. Молодёжная пресса Татарии (1917–1921). К., 1983; Печать, телевидение и радиовещание Татарии. 1917–1980: Сб. док. и материалов. К., 1981; Тыңлагыз, Казан сөйли! — Слушайте, говорит Казань! 1927–1997. К., 1998.

## IX.ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТ

19 йөз ахырында — 20 йөз башында Казан губернасында спорт хәрәкәтен үстерүнең алшартлары тудырыла. Казанда спорт җәмгыятьләре һәм берләшмәләре ачыла башлый: «Велосипедчы-һәвәскәрләр җәмгыяте» (1893), «Елга «Яхт-клубы» (1907), «Бөркет» (1908), «Көч һәм сәламәтлек» (1911), «Сокол» (1913), «Казан һавада очу җәмгыяте» (1914) һ.б. (к. *Спорт клублары*).

Окт. рев-циясеннән соң физкультура-спорт хәрәкәтен оештыру мәсьәләләре дәүләт дәрәҗәсендә хәл ителә башлый. Физкультура һәм спорт хәрәкәтен Казан губ. хәрби комис-ты һәм Казан губ. спорт берлеге каршында 1919 елда оештырылган физик тәрбия һәм спорт бүлеге җитәкли. 1920–30 елларда

физкультура-спорт эше «Татпечать», «Железнодорожник», «Флорида» физик тәрбия коллективларында, Үзәк физик тәрбия йортында, «Динамо», «Спартак» физкультура-спорт җәмгыятьләрендә активлаша (җиңел һәм авыр атлетика, йөзү, бокс, көрәш, шахмат, шашка, фехтование секцияләре эшли). Татарстанның аерым спортчылары һәм җыелма командалары җиңел һәм авыр атлетика, футбол, баскетбол (хатын-кызлар), йөзү, фехтование, чаңгыда узышу буенча илнең зур ярышларында (Идел буе хәрби округы олимпиадаларында, 1921, 1923–24; 1 нче Бөтенсоюз спартакиадасында, 1928; Идел буе спартакиадаларында, 1934–35; милли респ-каларның җәйге һәм кышкы спартакиадаларында, 1938–40) призлар яулыйлар. 1920 дә ТАССР Сәламәтлек саклау һәм Мәгариф халык комис-тлары каршында физик тәрбия буенча бүлекчәләр ачыла, алар беренче булып 1 нче һәм 2 нче баскыч мәктәпләрдә физкультура дәресләре программалары эшлиләр. 1926/27 уку елында физик тәрбия 69 мәктәптә алып барыла; 1934 елга укучыларның 80% ы мәҗбүри физкультура дәресләрендә шөгыльләнә. Респ-када «Готов к труду и обороне СССР» (ГТО, 1931–34) физкультура комплексын һәм Бердәм бөтенсоюз спорт классификациясе (1935–37) кертү физик тәрбия һәм спорт үсешенә этәргеч бирә, алар халыкка физик тәрбия бирү системасының программ-норматив нигезе булып тора. 1931 дә ГТО нормаларын — 450 кеше, 1940 еллар башында якынча 15 мең кеше тапшыра. 1936–37 дә Татарстанда студент яшьләрнең физкультура коллективларын берләштерүче профсоюзларның 10 ирекле спорт җәмгыяте («Буревестник», «Пламя», «Молния», «Старт», «Азот», «Темп», «Медик», «Крылья Советов», «Нефтяник», «Пролетарская победа»), ш.у. «Наука» спорт җәмгыяте оештырыла. 1930 елларның беренче яртысыннан авылларда физкультура хәрәкәте көчәя башлый; 1934 тә 196 колхоз-совхоз физкультура коллективлары һәм 33 район физкультура советы эшли. Физкультура һәм спорт оешмаларын квалификацияле белгечләр б-н тәэмин итүдә Казан физик тәрбия техникумы (1931–34) һәм Казан пед. уч-щесенең физкультура бүлеге (1934–37) сизелерлек роль уйный. Респ-када спортның спорт-техник төрләре үсешенә 1927 дә оештырылган Оборонага, авиация һәм химия төзелешенә ярдәм ирекле җәмгыяте (ОСОАВИАХИМ) (1951–91 дә — ДОСААФ, 1991 дән — ТРның РОСТО, 2008 дән «ТТның Төбәк оборона спорт-техник оешмасы — РОСТО (ДОСААФ)», 2013 тән «Татарстан Республикасының ДОСААФ» иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе) зур өлеш кертә. 1940 еллар башына Татарстанда якынча 9 мең физкультура коллективы, 30 ирекле спорт җәмгыяте советлары, физкультура һәм спорт б-н актив шөгыльләнүче якынча 35 мең кеше санала (шуларның 11 меңе авылларда); спортның 30 дан артык төре җәелдерелә. Бөек Ватан сугышы елларында ТАССР физкультура һәм спорт оешмаларының эшчәнлеге Кызыл Армия резервларын әзерләү һәм яраланган хәрбиләрнең сәламәтлеген һәм сугышка сәләтлелеген кайтару бурычларын хәл итүгә күчә. Хәрби хезмәткә чакыруга кадәрге әзерләү ирекле спорт җәмгыятьләре, физкультура коллективлары тарафыннан һәм гомуми хәрби өйрәнү пунктларында гамәлгә ашырыла, бу әзерлек чаңгы, җиңел атлетика һәм хәрби кросслар оештыруны, йөгерү, эстафета, ату буенча ярышларны, штык һәм кул сугышларын үз эченә ала. Сугышның беренче елларында хәрби-өйрәнү пунктлары җитәкчеләрен һәм инструкторларын (якынча 400 кеше әзерләнә), кул сугышы инструкторларын (2 мең кеше), чаңгычылар (1,5 мең кеше), дәвалау физкультурасы инструкторларын (200 дән артык кеше) әзерләүгә аерым игътибар бирелә. 1940–60 елларда «Динамо», «Спартак», «Наука», «Молния», «Урожай» һ.б. ирекле спорт җәмгыятьләренең эшчәнлеге активлаша. «Смена», «Трудовые резервы» балалар-яшүсмерләр ирекле спорт җәмгыятьләре булдырыла, физик тәрбия һәм спорт б-н шөгыльләнүчеләрнең саны сизелерлек арта. Татарстанның спорт командалары һәм аерым спортчылары чаңгы спорты, баскетбол, җиңел атлетика, бокс, йөзү, фехтование, футбол, шахмат буенча бөтенсоюз ярышларында уңышка ирешәләр. Татарстанның җыелма командасы СССР һәм РСФСР халыклары спартакиадаларында чыгышларының комплекслы нәтиҗәләре буенча 1956 да автономияле респ-калар командалары арасында 1 нче урынны ала. Спортчылар Э.И.Әүхәдиев, Г.Т.Бухарин, Г.М.Кондратьев, А.П.Курынов, А.Н.Мартюхин, Н.Л.Попов, Л.С.Сәлимуллин, Н.С.Тетёркин, В.И.Трусенёв, Е.М.Тарасова, Н.Ш.Фәсәхов, И.Л.Феоктистов, В.М.Шадрин, А.Ш.Шәйхетдинов һ.б. СССР, Европа, дөнья беренчелекләрендә һәм Олимпия уеннарында ишү, авыр атлетика, волейбол, ирекле көрәш, тимераякта фигуралы шуу, чаңгы спорты, шахмат һәм спортның башка төрләре буенча чемпион булалар һәм медальләр алалар.

Татарстанда физкультура-сәламәтләндерү эше системасы 1970–80 елларда яңа уңышларга ирешә. Даими рәвештә физкультура-спорт б-н шөгыльләнүчеләрнең саны 1986 да 2 млн. кешегә җитә. 1980 елларда балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләре, югары спорт осталыгы мәктәпләре эшчәнлегенә зур игътибар бирелә, аларда спортның 39 төре үстерелә. Аерулча баскетбол, спорт гимнастикасы, җиңел атлетика, чаңгы ярышлары, йөзү, пуля б-н һәм стендка ату, авыр атлетика, футбол, хоккей, шахмат һ.б. популярлаша. 1980 еллар ахырында спорт казанышлары дәрәҗәсе буенча Татарстан автономияле респ-калар арасында 1 нче урынны ала һәм СССРның союздаш респ-калары арасында Эстония б-н 8 нче урынны бүлешә. 1990 еллар ахырына Татарстанда 1901 спорт остасы (СССР), 68 халыкара класслы спорт остасы, 14 СССРның атказ. спорт остасы әзерләнә. СССРның атказ. тренеры исеме 8 кешегә, РСФСРның атказ. тренеры исеме 47 кешегә бирелә.

2000 еллар башында физкультура һәм спорт өлкәсендә гомуммилли дәүләт сәясәте массакүләм спорт үсеше, халыкның сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, югары казанышлы спорт үсеше өчен шартлар тудыру стратегияләрен гамәлгә ашыруга юнәлтелә. ТРда спортның 88 төре җәелдерелә (2009; шулардан якынча 40 олимпия төре — к. *Баскетбол, Бокс, Ирекле көрәш, Суда туплы уен, Волейбол, Спорт гимнастикасы, Академик ишү, ДЗЮДО, Җиңел атлетика, Чаңгы спорты, Спорт йөзүе, Фехтование, Футбол, Хоккей*). 2005 тә олимпия һәм параолимпия хәрәкәтен, спортны һәм спорт индустриясен үстергән өчен ТР 1 нче «Россия Олимпия Даны галереясы» Милли бүләгенә лаек була.

Респ-када (2016 га) 5 респ-ка физкультура-спорт җәмгыяте һәм берләшмәсе («Динамо», «Уңыш», «Спартак-Татарстан», «Буревестник», «Инвалидлар физкультура-спорт җәмгыяте»), 3,5 меңнән артык физик культура коллективы, балаларга спортның 72 төре буенча физкультура-спорт юнәлешендә өстәмә белем һәм тәрбия бирүче 176 учреждение (шулардан 30 балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе, 139 олимпия резервы махсус балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе, 7 физик әзерлек буенча балалар-яшүсмерләр спорт клубы бар), аларда шөгыльләнүчеләрнең гомуми саны — якынча 90 мең кеше; 251917 кеше шөгыльләнергә сәләтле 10578 спорт корылмасы эшли (ш.и. 44 стадион, 1993 спорт залы, 184 йөзү бассейны, ш.и. 162 ябык бассейн), ясалма бозлы 42 ябык спорт объекты, 10 җиңел атлетика һәм 1 футбол манежы, спортның ату төрләре буенча 251 корылма (236 тир, 1 ату урыны һәм 14 стенд), 3 атлар ябык манежы, 52 чаңгы базасы, 5172 яссы мәйданлы спорт корылмасы, 2 ишү базасы, 2000 нән артык стандарт булмаган спорт залы, физкультура һәм спорт б-н шөгыльләнергә яраклаштырылган бина исәпләнә.

Соңгы елларда 2011–15 елларга исәпләнгән «Уңайлы мохит» респ-ка программасын гамәлгә ашыру кысаларында мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең физкультура-спорт б-н шөгыльләнүе активлаша (2016 га физкультура-спорт б-н шөгыльләнүче инвалидлар — 33061 кеше, яисә гомуми санның якынча 10,22 % ын тәшкил итә).

2011 дә ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы каршындагы Үзәк спорт клубы үзгәртелә һәм Спорт әзерлеге үзәге буларак эшли башлый, аның максаты — спортның РФ Спорт, туризм һәм яшьләр сәясәте министрлыгы билгеләгән 29 төп төре буенча Татарстанның әйдәп баручы спортчылары арасыннан Россия спорт җыелма командалары резервын әзерләү.

Соңгы 10 елда Казанда Россия һәм Европа күләмендәге зур спорт корылмалары файдалануга тапшырыла: «Баскетхолл», «Татнефть-арена» Боз спорт сарае, Чирәмдәге хоккей үзәге, «Казан» ат спорты комплексы, «Ак Барс» көрәш сарае, Казан теннис академиясе, Спортның су төрләре сарае, спортның ишү төрләре, волейбол, гимнастика, бокс һәм өстәл теннисы, пляж волейболының шөгыльләнү үзәкләре, «Свияга» стендка ату комплексы, «Казан-арена» футбол стадионы һ.б.

Спорт индустриясе өлкәсендә 8915 кеше эшли, шуларның 4 меңнән артыгы югары белемле һәм якынча 2 меңе махсус урта белемле. Физкультура һәм спорт б-н даими шө-

гыйльләнүчеләр саны 1 млн.нан артык (барлык респ-ка халкының 29% ы).

Хәзерге вакытта ТРда кадрлар потенциалын гамәлгә ашыручы оешмалар: 2010 нан — Идел буе дәүләт физик тәрбия, спорт һәм туризм академиясе (Казан; Чаллыда ф-лы һәм физик тәрбия көллияте бар), 2011 дән — Казан ун-тының физик тәрбия, спорт һәм терәкләндерү медицинасы ин-ты (1949–2011 дә Татар гуманитар-педагогика ун-ты каршында ф-т), 2005 тән — Казан олимпия резервы уч-щесе, 1966 дан — Әлмәт физик тәрбия көллияте (2010 га кадәр — техникум), 1966 дан — Тәтеш пед. көллиятенең физик тәрбия бүлеге (2010 га кадәр — уч-ще). ТР командасы — 1 нче Бөтенроссия универсиадасында (гомумкоманда зачётында, 2008), спортның кышкы (2007, 2013, 2015; көмеш, 2011) һәм җәйге (2011, 2013, 2015; көмеш, 2007) төрләре буенча Укучыларның Идел буе федераль округы спартакиадасында, Россия яшьләренең 3 нче Спартакиадасының 2 нче этабында җиңүче. ТР «Инвалидлар физкультура-спорт җәмгыяте» — Бөтенроссия иң яхшы физкультура-спорт эшләре смотр-конкурсында җиңүче (2007).

Россия чемпионатларының югары лигаларында Казан командалары спортның төрле төрләре буенча чыгыш ясый: «Ак Барс» спорт клубы хоккей командасы — Россия чемпионы (1998, 2006, 2009, 2010), Россия чемпионатында көмеш (2000, 2002, 2007), бронза (2004) медаль ала, Европа чемпионнары Кубогы (2007), Континенталь кубок (2008), континенталь хоккей лигасының Ю.А.Гагарин исем. кубогы (2009, 2010); Башкортстан Президенты (2003), Прага (2008), Түбән Новгород өлкәсе губернаторы (2014), Латвия тимер юлы (2014) кубокларына сезонара турнирларда һ.б.да җиңүче. «Уникс» баскетбол клубы командасы Суперлига чемпионатларында көмеш (2001, 2002, 2004, 2007), бронза (2000, 2003, 2005, 2008, 2009–11) медальләр ала, Россия (2003, 2009, 2014), Европа (2010–11) кубоклары иясе, ФИБА-Европа лигасы чемпионы (2004); «Зенит» волейбол клубы командасы Россия чемпионы (2006/07, 2008/09, 2009/10, 2010/11, 2011/12, 2013/14, 2015/16), Россия чемпионатында бронза медаль ала (2003/04, 2004/05, 2007/08, 2012/13), Россия Кубогы (2004, 2007, 2009, 2014, 2015), Суперкубогы (2010–2012, 2015) иясе, чемпионнар лигасы җиңүчесе 2007/08, 2011/12, 2014/15, 2015/16. «Рубин» футбол клубы командасы — Россия чемпионы (2008, 2009), Россия чемпионатында бронза медаль ала (2003, 2010), Россия Кубогы (2012), Бергәлек кубогы (2010), Россия Суперкубогы (2010, 2012) иясе. «Синтез» суда туплы уен командасы — Россия чемпионы (2006/07), Россия чемпионатында көмеш (2005/06, 2007/08, 2009/10, 2011/12, 2013/14), бронза (2004/05, 2008/09, 2010/11) медальләр ала; Россия Кубогы (2005, 2010), «Лен Трофи» Кубогы (2006/07) иясе. Чирәмдә хоккей буенча «Динамо» командасы — Россия чемпионы (2003–08, 2010–15), Россия Кубогы иясе (2001, 2005), «Динамо-Казан» волейбол клубы (хатын-кызлар) командасы — Россия чемпионы (2011–15), Россия Кубогы иясе (2010, 2012), клуб — дөнья чемпионатында (2014), чемпионнар лигасында (2014) җиңүче, «Динамо-Казан» туплы хоккей командасы — Россия чемпионатында җиңүче (2010/11), көмеш (2011/12), бронза (2008/09, 2012/13, 2013/14) медальләр ала, Россия Кубогы (2009, 2013), Дөнья Кубогы (2010), Эдсбюн чемпион Кубогы (2009) иясе. Спорт йөк машиналары классында дөнья автоспорты «КАМАЗ-Мастер» командасы — ралли-рейдлар буенча берничә тапкыр Дөнья Кубогы иясе, трансконтиненталь югары категория катлаулылыктагы «Париж–Дакар» супермарафонында күп тапкыр җиңүче һәм приз алучы (1989 дан).

2013 нең 6 июленнән 17 июленә кадәр Казанда 27 нче Бөтендөнья студентлар җәйге Универсиадасы уза, анда 162 илдән 7980 спортчы һәм 3798 рәсми зат катнаша. 64 спорт объектында медальләрнең 351 комплектына ярышлар уздырыла. Спорт менеджменты өлкәсендәге казанышлар өчен Халыкара бүләк тапшыру тантанасында Казан «Халыкара чаралар уздыру өчен дөньяда иң яхшы урын» дигән махсус приз ала, 2013 елгы Универсиада «Иң инновацион вакыйга», «Чара үрнәге» номинацияләрендә җиңүче булып танылa. Татарстан спортчылары Универсиадада 40 медаль яулыйлар, шуларның 20 се алтын, 10 сы көмеш, 10 сы бронза (к. *Универсиада*).

2015 нең 24 июленнән 9 августына кадәр Казанда спортның су төрләре буенча 16 нчы Дөнья чемпионаты уза, анда 190 илдән 2413 спортчы һәм 1495 рәсми зат катнаша. 4 спорт объектында медальләрнең 75 комплектына ярышлар уздырыла. Татарстаннан 5 спорт төре буенча 11 спортчы катнаша.

2010 да Футбол халыкара федерациясе (ФИФА) башкарма ком-ты 2018 дә Россиядә футбол буенча 21 нче дөнья чемпионаты матчларын уздыру турында карар кабул итә. 2012 дә Казан футбол ярышлары узачак 11 шәһәр исемлегенә кертелә. 2014 тә РФнең Акробатик рок-н-ролл федерациясенең Татарстан бүлеге оеша.

2016 ел башына ТРда 353 СССРның спорт остасы, Россиянең халыкара класслы спорт остасы, 83 СССРның, Россиянең атказ. спорт остасы әзерләнә. СССРның, Россиянең атказ. тренеры исеме 108 кешегә, ТРның атказ. физик тәрбия хезмәткәре — 494, РФнең атказ. физик тәрбия хезмәткәре исеме 23 кешегә бирелә. 2016 елда респ-кадан Олимпия уеннарына 67 спортчы җибәрелә; 32 медаль, ш.и. 17 алтын, 8 көмеш, 7 бронза медаль яулана (к. *Олимпия уеннары*).

*Әд.:* История физической культуры и спорта в Республике Татарстан. Наб. Челны, 1999.

### X. ТР ДӘҮЛӘТ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ОЕШМАЛАРЫНДА ТАТАРЛАРНЫҢ РЕСПУБЛИКАДАН ЧИТТӘ ТУПЛАНЫП ЯШӘҮ УРЫННАРЫНДАГЫ МӘДӘНИ-АГАРТУ ЭШЕ

ТР Конституциясенең 14 нче маддәсе һәм «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» 2007 ел 24 июль килешүе нигезендә респ-ка хакимият органнары һәм ш.у. иҗат берләшмәләре, җәмәгать оешмалары Татарстаннан читтә яшәүче татарларга мәдәниятне, телне үстерүдә һәм милли гореф-гадәт үзенчәлекләрен саклап калуда ярдәм күрсәтә. ТР Хөкүмәтенең РФнең 69 субъекты б-н төзелгән килешүләренә шул төбәкләрдәге татарларның тел һәм мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлтелгән махсус пунктлар кертелгән. Респ-кадан читтә яшәүче татарларның милли-мәдәни тормышын, нигездә, ТРның 5 тулы вәкаләтле (РФ дә, Казакъстан Респ-касында, Төркия Респ-касында, Франция Респ-касында, Төрекмәнстанда), 5 даими (Свердловск өлкәсендә, С.-Петербург ш. һәм Ленинград өлкәсендә, Башкортстан Респ-касында, Әзәрбайҗан Респ-касында, Кырым Респ-касы һәм Севастополь шәһәрендә), 12 сәүдә-икътисад (Ханты-Манси автономияле округында, Түбән Новгород өлкәсендә, Саратов өлкәсендә, Украинада, Үзбәкстан Респ-касында, Куба Респ-касында, Финляндия Респ-касында, Чехия Респ-касында, Швейцария Конфедерациясендә, АКШта, Дубайда (БГӘ), Кытай Халык Респ-касында (КХР)) вәкиллекләре оештыра. ТРдан читтә яшәүче татарларның икътисади эшчәнлеген оештыручы мөһим үзәкләр булып сәүдә йортлары (2014 тә Россия төбәкләрендә — 24, чит илләрдә 5 сәүдә йорты эшли) тора. ТРдан читтә яшәүче татарларның милли-мәдәни яшәешен оештыруда РФнең 63 субъектында — 196, дөньяның 41 илендә 135 милли-мәдәни оешманы берләштергән Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма ком-ты күптөрле эш алып бара. Бөтендөнья татар конгрессы составына Татарларның милли-мәдәни федераль автономиясе керә. Эшләү дәверендә конгресс 5 корылтай уздыра (к. *Бөтендөнья Татар конгрессы корылтайлары*). 4 нче корылтай (2007) эшендә 1 меңләп делегат һәм 28 илдән кунак катнаша, ш.и. Көньяк Африка Респ-касы, Израиль, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Словакия, Әфганстан кебек илләрдән беренче тапкыр татарлар килә. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-ты респ-ка хакимияте б-н бергә берничә юнәлештә эш алып бара. Иң мөһимнәре: ТРдан читтә яшәүче татарларның милли-мәдәни яшәеше үзәге булган учреждениеләрне оештыру һәм аларга ярдәм итү; милли мәгариф системасын торгызу һәм саклау (5 тапкыр татар теле һәм әдәбияты укытучыларының бөтенроссия съезды, татар галимнәренең ТР ФА б-н берлектә халыкара форумнары үткәрелә, 2007, 2011), яшьләр хәрәкәтен оештыру һәм активлаштыру (2004, 2006, 2008, 2010, 2012, 2014, 2016 елларда — барлыгы 7 бөтендөнья татар яшьләре форумы була). Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-ты каршында Бөтенроссия «Татар гаиләсе» иҗтимагый фонды, «Татарча көрәш» милли көрәш спорт федерациясе һәм «Россиядәге татар авыллары» бөтенроссия иҗтимагый оешмалары, Татар эшмәкәрләренә булышлык күрсәтү бөтендөнья ассоциациясе эшли. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы РФнең 32 төбәге һәм 2 БДБ иле б-н килешү төзи. Бу багланышлар төрле мәдәниятләр мәга-

рифен оештыру һәм саклау чаралары аша тормышка ашырыла. 2014 тә Түбән Новгород, Самара, Саратов, Свердловск, Чиләбе өлкәләрендә, БРда һәм Чуаш Респ-касында «Татар мәгарифе көннәре» үткәрелә. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы РФ төбәкләрендәге гомуми белем учреждениеләренә, югары һәм урта махсус уку йортларының (Тубыл, Уфа, Эстәрлетамак, Ижевск, Әстерхан һәм Төмән пед. югары уку йортлары) татар бүлекләренә ярдәм күрсәтә. 2000 нән Мәскәү пед. ун-тында рус теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләнә, алар өстәмә «татар теле һәм әдәбияты» белгечлеге алып чыга (Татарстан, Башкортстан, Ханты-Манси автономияле округы, Пермь крае һәм Түбән Новгород өлкәсеннән студентлар укый). Татар пед. кадрлары РФнең 16 пед. уч-щесендә һәм көллиятендә әзерләнә. Ватандашларга ярдәм йөзеннән федераль программаны тормышка ашыру кысаларында ТРда 2004 тән БДБ һәм якын чит илләрдән килүче талантлы татар яшьләрен югары уку йортларына конкурссыз алу оештырыла. 2006–2008 дә Татарстан югары уку йортларында Әзәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Үзбәкстан респ-калары абитуриентлары һәм ш.у. Кытайдагы Шөнҗан-Уйгыр автономияле округының Өремче һәм Голҗа шәһәрләрендә яшәүче татар диаспорасы вәкилләре өчен 200 урынга ташлама карала. РФ һәм БДБ илләренең гомуми белем учреждениеләренә уку-укыту программалары, дәреслекләр, методик һәм матур әдәбият, интерактив кулланмалар җибәрелә. 2014 тә ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы фондыннан РФ субъектлары мәгариф учреждениеләренә 12345 данә дәреслек һәм матур әдәбият китабы бушлай бирелә, 2014/15 уку елында РФнең 35 субъектындагы 1189 гомуми белем бирү учреждениесендә фәннәр татарча укытыла, татар теле һәм әдәбияты фән буларак өйрәнелә. ТР Президенты ярдәме б-н «Ана теле» татар телен дистанцион өйрәнү һәм «Татар иле» татар мәгълүмат-ресурс социаль челтәрен төзү проектлары тормышка ашырыла. Татарстан китап нәшрияты РФнең 20 дән артык төбәген татар дәреслекләре һәм уку әсбаплары б-н тәэмин итә.

ТР министрлыклары һәм ведомстволары РФ төбәкләрендәге сәләтле, талантлы балаларга ярдәм итү, шартлар тудыру буенча эш алып бара. Төбәкара татар теле һәм әдәбияты олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм сәләтле укучыларга Казан ун-тының филол. ф-тына керү өчен ташламалар карала. Казанда РФ субъектларында яшәүче балалар өчен төбәкара җәйге савыктыру лагере оештырыла, анда алар сөйләм телен камилләштерәләр, татар милләтенең мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре б-н танышалар. 2014 тә лагерьда РФнең 24 субъектыннан 1,5 мең укучы ял итә. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы татар теле һәм әдәбияты буенча төбәкара һәм халыкара олимпиадалар уздыра. Татарстан мәдәнияте өлкәсендә РФнең 21 төбәге һәм Төркия б-н туган телне өйрәнүдә татар халкына ярдәм күрсәтүгә, балалар һәм яшьләрне милләтебезнең милли-мәдәни хәзинәсе б-н таныштыруга юнәлтелгән ведомствоара килешүгә кул куйды. ТР Мәдәният министрлыгы татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә даими рәвештә Татар мәдәнияте көннәрен уздыра (2005 тә — Томскида, 2007 дә — Төмәндә, 2008 дә — Саратовта, 2009 да — Оренбург өлкәсендә). Ел саен татар иҗат коллективлары гастрольләре оештырыла. 2008 дән Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-ты һәм ТР Мәдәният министрлыгы каршындагы Татар фольклорын өйрәнү үзәге ярдәмендә татар фольклор коллективларының Бөтенроссия «Түгәрәк уен» фестивале уздырыла (2008 дә — Ульянов шәһәрендә, 2009 да — Төмәндә, 2010 да — Свердловск өлкәсендә, 2011 дә — Пермь краенда, 2012 дә — Самара өлкәсендә, 2013, 2014 тә — ТРда, 2015 тә — Мари Респ-касында, 2016 да — Кырым Респ-касында). Респ-кадан читтә яшәүче татарларның рухи ихтыяҗын тулырак канәгатьләндерү өчен татар мәдәни үзәкләре (Мәскәү, Әстерхан, Йошкар-Ола, Магнитогорск, Новосибирск, Тубыл, Томск, Ульянов, Киев, Аделаида, Гданьск, Нью-Йорк, Сан-Франциско, Хельсинкида эшли) оештырыла; «Татарстан-Яңа гасыр» телерадиотапшырулар компаниясе тапшыруларын Россиянең татарлар яшәгән Европа өлешенә, Урал төбәгенә, Көнбатыш Себер, Ерак Көнчыгышка, БДБ илләренең барысына да диярлек, якын чит илләргә, Көнчыгыш һәм Үзәк Европага, Скандинавия, Урта Азия, Төньяк Һиндстан, Кытай һәм Японияга трансляцияли. 1990 еллар ахырыннан ТРдан читтә тупланып яшәүче татарларның милли-мәдәни яшәешен оештыруда мөһим рольне төрле милләт вәкилләрен берләштерүче Сабан туе үти башлый. 2001 дән РФдә — федераль Сабан туйлары (2001 дә — Саратовта, 2002 дә — Тольятти, 2003 тә — Димитровград, 2004 тә — Йошкар-Ола, 2005 тә — Түбән Новгород, 2006 да — Саранск, 2007 дә — Чиләбе, 2008 дә — Әстерхан, 2009 да — Ульянов, 2010 да — Ижевск, 2011 дә — Екатеринбург, 2012 дә — Владивосток, 2013 тә — Төмән, 2014 тә — Томскида, 2015 тә — Красноярскида, 2016 да —Түбән Новгородта); 2010 нан Бөтенроссия авыл Сабан туйлары (2010 да — Самара өлкәсенең Похвистнево р-ны Гали а., 2011 дә — Чуаш Респ-касының Батыр р-ны Шыгырдан а., 2012 дә — Чиләбе өлкәсенең Кызыл Армия р-ны Дубровка а., 2013 тә Пермь краеның Барда районы Барда а., 2014 тә — Волгоград өлкәсенең Светлый Яр р-ны Кече Чапурин а., 2015 тә — Оренбург өлкәсенең Сакмар р-ны Татар Каргалысы а., 2016 да Ульянов өлкәсенең Иске Кулаткы авылында) үткәрелә.

ТР Мәдәният министрлыгы татар иҗат коллективлары б-н берлектә Татарстаннан читтә Сабан туе үткәрүне оештыра. 2007 дә РФ субъектларына бу максатларда 16 проф. (2 меңләп кеше) һәм 200 дән артык үзешчән сәнгать коллективы юнәлә. Мәдәният һәм милли гореф-гадәт үзенчәлекләрен саклап калуда татар авылларының мөһим ролен исәпкә алып, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-ты 2008 дә Бөтенроссия татар авыллары ассоциациясен оештыра, анда Россиянең 100 ләп иң зур татар торак пунктлары керә. Соңгы елларда татар халкын милли рухи хәзинәләр тирәсендә туплауда дини оешмаларның роле көннән-көн үсә. Алар тырышлыгы б-н РФнең күп кенә төбәкләреннән, якын һәм ерак чит илләрдән килүче татарлар Россия мөселманнарының Болгар шәһәрендә ел саен үткәрелә торган Идел буе Болгар дәүләтендә ислам кабул ителүгә багышланган «Изге Болгар җыены»нда катнаша.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ ҺӘМ АЗЫ́К-ТӨЛЕ́К МИНИ́СТРЛЫГЫ**, тарихы Җир ком-тлары турында 1917 ел 21 апрель нигезләмәсенә таянып 1917 нең июнендә оештырылган Казан губерна җир ком-тыннан һәм Казан губерна җир идарәсеннән башлана; алар Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна советы гомуми җыелышының 1918 ел 26 февраль карары б-н — Казан Совет Эшче-Крәстиян Респ-касының Игенчелек комис-ты, Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советы Казан губерна башкарма ком-тының 1918 ел 16 май һәм Казан губерна ХХСның 1918 ел 3 июнь карарлары б-н — Казан губерна игенчелек комис-ты, Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы Казан губерна башкарма ком-тының 1918 ел 15 октябрь карары б-н — губерна башкарма ком-тының игенчелек бүлеге, БҮБК һәм РСФСР ХКСның 1920 ел 27 май Декреты һәм ТАССР ҮБКның 1920 ел 28 сентябрь карары б-н ТАССР Игенчелек халык комис-ты итеп үзгәртелә. Элек Халык комис-ты җир мөнәсәбәтләрен, соц. а.х.н. оештыру, соц. җир төзелешен һәм җирдән файдалануны гамәлгә ашыру, аграр эшчәнлекне, урман хуҗалыгын үстерү мәсьәләләре һ.б. б-н шөгыльләнә, 1930 еллардан а.х.ның барлык тармаклары үсеше, колхоз кадрлары һәм белгечләре әзерләү, колхозларда эшне оештыру, акча һәм матди ресурсларны бүлү, җир төзелеше эшләрен башкару һәм колхозларның үзләренә тапшырылган җирләрдән дөрес файдалануын контрольдә тоту, вет. хезмәте күрсәтү һәм дәүләт вет. инспекциясе эшчәнлеге, ш.у. а.х.н. электрлаштыру, дәүләт саклаулыклары, урман эшкәртү һәм урманнарны саклау, МТСлар һәм машина-трактор остаханәләре б-н җитәкчелек итә. 1920 елларда адм.-оештыру, финанс-исәп, җир төзелеше һәм мелиорация, игенчелек һәм а.х., а.х. белеме бирү, а.х. тәҗрибә эше идарәләрен, нәшрият, стат. бүлекләрен; 1930 елларда бөртеклеләр (машина-техника, агротехника, орлыкчылык бүлекләре), терлекчелек, җирле әһәмияткә ия урманнар, вет. идарәләрен, җир төзелеше һәм мелиорация, капиталь төзелеш, планлаштыру-финанс, исәп-стат. бүлекләрен; 1940 елларда агротехника һәм механикалаштыру, сортлар, җиләк-җимеш һәм яшелчә, терлекчелек идарәләрен, җир төзелеше, планлаштыру-икътисад, финанс, капиталь төзелеш бүлекләрен, орлыкчылык контроле инспекциясен үз эченә ала. Халык комис-ты карамагына район (1930 елларга кадәр — кантон) җир бүлекләре, колхозлар, совхозлар, җиләк-җимеш һәм яшелчә питомниклары, МТСлар, техникумнар, һөнәри-техник уч-щеләр һәм а.х. мәктәпләре, дәүләт ат з-длары, Татарстан терлекчелек тәҗрибә

станциясе, «Сельхозснабжение», «Агролессем», «Ветснабсбытторг» конторалары, Казан респ-ка ипподромы, «Ремтрест», дәүләт тимерчелеге керә. ТАССР ҮБКна (1938 гә кадәр), ТАССР ХКСна һәм РСФСРның шул ук исемдәге Халык комис-тына буйсына.

ТАССР Игенчелек халык комис-ты ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы б-н — ТАССР Игенчелек министрлыгы, ТАССР ЮС Президиумының 1947 ел 3 март Указы б-н — ТАССР А.х. министрлыгы, ТАССР ЮС Президиумының 1953 ел 30 апрель карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1953 ел 30 май Указы б-н — ТАССР А.х. һәм хәзерләүләр министрлыгы, ТАССР ЮС Президиумының 1953 ел 11 декабрь карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1953 ел 22 декабрь Указы б-н — кабат ТАССР А.х. министрлыгы, ТАССР ЮС Президиумының 1962 ел 31 март Указы б-н ТАССР А.х. продуктларын җитештерү һәм әзерләүләр министрлыгы, ТАССР ЮС Президиумының 1965 ел 9 март Указы б-н — ТАССР А.х. министрлыгы, ТАССР ЮС Президиумының 1985 ел 12 декабрь Указы б-н — ТАССР Агросәнәгать ком-ты, ТССР ЮСның 1991 ел 7 февраль карары б-н ТССР (1992 дән ТР) А.х. һәм азык-төлек министрлыгы итеп үзгәртелә. А.х., ит һәм сөт, 1985 тән — азык-төлек сәнәгате, продукция хәзерләүләр, колхозларда, совхозларда, крәстиян хуҗалыкларында һәм Агросәнәгать комплексы пр-тиеләрендә төзелеш, хезмәт күрсәтү һәм матди-техник тәэминат эшләре б-н җитәкчелек итүне, ашлык кабул итү һәм эшкәртү, җирләрне мелиорацияләү, урман һәм балыкчылык хуҗалыклары өлкәләрендә тармакара идарәне гамәлгә ашыра. Хәзерге вакытта Министрлык дәүләт сәясәтен уздыра һәм Агросәнәгать комплексы, респ-када азык-төлек тәэминаты б-н идарә итә. 1970 елларда аның составына планлаштыру-икътисад, хезмәт һәм хезмәт хакы, механикалаштыру һәм электрлаштыру, игенчелек һәм орлыкчылык, терлек азыгы җитештерү, терлекчелек, бәрәңге һәм яшелчә игү, вет., алдынгы тәҗрибә куллану, колхоз эшләре, җир төзелеше, орлыкчылык һәм чөгендер игү совхозлары, хуҗалыкара кооперация, контроль-ревизия, мелиорация, продукцияне сату һәм стандартлаштыру, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы, кадрлар, финанс бүлекләре, бухгалтерия, дәүләт авыл техник күзәтчелеге, дәүләт орлыкчылык инспекцияләре; 1980 еллар уртасыннан — Агросәнәгать комплексын планлаштыру һәм аның социаль-икътисади үсеше, нормалаштыру, хезмәтне оештыру һәм хезмәт хакы, финанс һәм кредитлар, бухгалтерия исәп-хисабы, контроль-ревизия, үсемлекчелек продукциясе җитештерү һәм эшкәртү, җирдән файдалану һәм җир төзелеше, мелиорацияләнгән җирләрдән файдалану һәм терлек азыгы җитештерү, терлекчелек продукциясе җитештерү һәм эшкәртү, вет., механикалаштыру һәм электрлаштыру, транспорттан файдалану, аңа техник хезмәт күрсәтү һәм хәрәкәт куркынычсызлыгы, кадрлар һәм уку йортлары, бәрәңге игү, яшелчәчелек һәм яшелчә культуралары орлыкчылыгы, гомуми, Агросәнәгать ком-ты эшләре бүлекләре, колхозлар һәм соц. ярыш казанышларын гамәлгә кертү һәм пропагандалау, гражданнар оборонасы һәм махсус эш бүлекчәләре, хуҗалыкара кооперация, ярдәмче хуҗалыклар, сәнәгать пр-тиеләре, шәхси ярдәмче хуҗалыклар һәм күмәк бакчачылык төркеме, а.х. продуктлары әзерләү һәм аларның сыйфаты, җирләрне файдалану һәм саклау, авыл техник күзәтчелеге дәүләт инспекцияләре; 21 йөз башыннан — игенчелек, терлекчелек, азык-төлек җитештерү һәм эшкәртү сәнәгате, финанс, ведомстволар карамагындагы оешмаларның хуҗалык эшчәнлегенә аудит тикшерүе, кредит, салым һәм исәпкә алу сәясәте, инвестиция сәясәте, хезмәтне саклау, мобилизацион әзерлек һәм гадәттән тыш хәлләр, механикалаштыру һәм электрлаштыру, маркетинг һәм лизинг эшчәнлеге, ягулык-майлау материаллары, аграр үзгәртеп корулар һәм хезмәтне мотивацияләү, дәүләт милке б-н идарә итү, икътисади анализ һәм планлаштыру, кадрлар һәм кадрлар сәясәте, гомуми, юридик бүлекләр, мәгълүмат-аналитика секторы, продукция хәзерләү һәм аның сыйфаты буенча дәүләт инспекциясе керә. Министрлык системасына 39 район агросәнәгать берләшмәсе (РАПО), 606 колхоз, 282 совхоз, 21 нәсел үрчетү хуҗалыгы, 8 тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгы, 22 инкубатор-умартачылык станциясе, 16 кошчылык ф-касы, 8 җитештерү берләшмәсе, 10 төзелеш оешмасы, 60 ремонт-техника пр-тиесе, 2 күчмә механикалаштырылган колонна, респ-ка вет.-сан. отряды, 39 вет. лаб-се, 39 терлек авыруларына каршы көрәш станциясе, 42 вет. дәваханәсе, 8 шәһәр вет. станциясе, 35 вет. участогы, 26 вет. пункты, Татарстан а.х. б-н идарә итү мәктәбе, 1 механика-технол., 3 а.х. техникумы, 3 совхоз-техникум, 10 башка оешмалар (1986), хәзерге вакытта 840 тан артык пр-тие һәм учреждение карый. ТР Президентына, ТР Министрлар Кабинетына (1991 гә кадәр — ТАССР МСна) һәм РСФСРның шундый ук Министрлыгына буйсына.

Халык комиссарлары һәм министрлар: Ю.Н.Вәлитов (1920–23), И.Г.Әмиров (1923–27), Ю.Я.Якубов (1925–26), М.Ә.Әхмәтшин (1926–27), Н.В.Петров (1927–29), Г.И.Искәндәров (1929–37), Ш.Г.Әбсәләмов (1937–38), П.П.Черзор (1938–40), В.И.Марданов (1940–41), А.А.Косушкин (1941 — 1942 нең феврале), Н.П.Шибдин (1942 нең марты–июле), Ә.М.Хөсәенов (1942 июле–1943), С.Б.Талипов (1943–48), Г.К.Ганиев (1948–1957 нең мае), А.А.Скочилов (1957 нең мае–июле), Ф.И.Гущин (1957 нең октябре–1959), Ү.Г.Биктимеров (1959–62), В.И.Остаплюк (1962–63), Б.П.Мартынов (1963–65), Г.Ф.Мамаков (1965–67), Ф.Х.Минушев (1967–71), У.Ш.Җиһаншин (1971–83), М.Ә.Сираев (1983–85), Г.Н.Захаров (1985–86), Н.Г.Энвальд (1986–90), Г.В.Гәрәев (1990–91), Ф.С.Сибагатуллин (1991–96), В.П.Васильев (1996–99), М.Г.Әхмәтов (1999 дан).

Ш.у.к. *Агросәнәгать комплексы*, *Авыл хуҗалыгы.*

*Е.Б.Долгов.*

**«ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ АЛДЫНДАГЫ́ КАЗАНЫШЛА́Р ӨЧЕ́Н» ОРДЕНЫ**, ТРның дәүләт бүләге. ТРның 2004 ел 24 март Законы б-н гамәлгә кертелә. ТР дәүләтчелеген, икътисад, мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәнгать һәм спортны үстерү, кеше хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итүдә зур казанышларга ирешкән, җәмәгать тәртибен саклауда кыюлык һәм батырлык күрсәткән гражданнар өчен булдырыла. Орден б-н ТР Президенты бүләкли. ТР Президентының 2004 ел 16 июнь һәм 25 ноябрь Указлары буенча орден билгесен нигезендә алтын һәм көмеш йөгертелгән, кырлары шомартылган сигез нур булган көмеш йолдыз тәшкил итә. Йолдызның кара-каршы очлары арасы — 50 *мм*. Йолдыз үзәгендә — барс сурәте төшерелгән, 20 *мм* диаметрлы алтын йөгертелгән түгәрәк медальон. Медальон әйләнәсендә ике кабарынкы кайма арасындагы яшел эмаль җирлекне татар халык орнаменты рәвешендәге бизәк били, түбәнге өлештә «Татарстан» язуы урнаштырылган. Билгенең арткы ягында — номер. Билге яшел-ак-кызыл төстәге муар тасма тарттырылган биш почмаклы кыса б-н тоташа. Тасманың киңлеге — 24 *мм*, яшел һәм кызыл буйларның киңлеге 11 әр *мм*, ак буйның киңлеге — 2 *мм*. Орден яшел-ак-кызыл төстәге муар тасма тарттырылган 10×24 *мм* зурлыктагы турыпочмаклы кыса рәвешендәге орден планкасы б-н бергә бирелә. Тасма үзәгендә алтынланган лалә урнаштырылган. Кызыл һәм яшел буйларның киңлеге 11 әр *мм*, ак буйнысы — 2 *мм*. 2015 нең 1 гыйнварына әлеге бүләккә 153 кеше лаек булган.

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ АРБИТРА́Ж МӘХКӘМӘСЕ́**, ТРның идарә өлкәсендәге, пр-тие, учреждение, оешмалар, ш.и. эшмәкәрлек б-н шөгыльләнүче гражданнар арасында икътисади бәхәсләр буенча хөкем итүне гамәлгә ашыручы мәхкәмә органы. РСФСР ХКСның 1922 ел 21 сентябрь карары нигезендә 1922 елның 23 сентябрендә Икътисади Киңәшмә каршындагы (1926 дан ТАССР ХКС каршындагы) Югары арбитраж комиссиясе буларак оештырыла; СССР ҮБКның һәм ХКСның 1931 ел 3 май карары б-н исеме ТАССР ХКС (1946–87 дә — МС) каршындагы Дәүләт арбитражы дип алыштырыла. Башлыча пр-тиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр тарафыннан дәүләт дисциплинасын һәм шартнамә йөкләмәләрен мәҗбүри рәвештә үтәүгә юнәлтелгән идарә эшчәнлеге б-н шөгыльләнә. Хөкүмәт билгеләгән баш дәүләт арбитрыннан, аның урынбасарыннан, дәүләт арбитрларыннан тора.

ТР ЮСның 1992 ел 22 май карары б-н ТР Дәүләт арбитражы — ТР Югары арбитраж мәхкәмәсе, ТРның 2001 ел 25 октябрь Законы б-н ТР Арбитраж мәхкәмәсе итеп үзгәртелә. Аның составына рәис, рәис урынбасарлары, мәхкәмә әгъзалары керә. ТР А.м. судьялары РФ Югары арбитраж мәхкәмәсе рәисе тәкъдиме б-н һәм ТР Дәүләт Советы б-н килештерелеп, вәкаләтләре вакыты чикләнмичә, РФ Президенты тарафыннан билгеләнә (1995 кә кадәр ТР ЮСнда сайланалар).

ТР А.м. Пленум, икътисади бәхәсләр буенча эшләрне хәл итү, идарә өлкәсендә килеп чыккан эшләрне ачыклау, закон нигезендә гамәлгә кермәгән карарларның законлы һәм нигезле булуын кассация тәртибендә тикшерү, закон көченә кергән карарларның законлы һәм нигезле булуын күзәтчелек рәвешендә тикшерү коллегияләре составында эшли. Судьялар бәйсез һәм фәкать законга буйсына. ТР А.м. вәкаләтләренә: эшләрне беренче һәм апелляция инстанцияләре мәхкәмәсе сыйфатында, яңадан ачыкланган хәлләргә таянып карау; теләсә кайсы инстанциядә каралучы эштә кулланылган яисә кулланылырга тиешле законның Конституциягә туры килүен тикшерүне сорап РФ Конституция мәхкәмәсенә мөрәҗәгать итү; законнарны һ.б. хокукый актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү, мәхкәмә практикасын өйрәнү һәм гомумиләштерү; мәхкәмә статистикасын анализлау керә. ТР А.м. карарлары, күрсәтмәләре һәм билгеләмәләре катгый көчкә ия, аларның үтәлеше мәҗбүри.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ АРХИТЕ́КТОРЛАР БЕРЛЕГЕ́**, иҗади проф. оешма, 1934 елда Совет архитекторлары берлегенең Татарстан ф-лы буларак оештырыла; 1938 дән Совет архитекторларының Татарстан бүлеге, 1955 тән СССР Архитекторлар берлегенең Татарстан оешмасы (1981 дән — РСФСР Архитекторлар берлеге), 1992 дән хәзерге исемендә. Берлекнең максатлары — һөнәри мәнфәгатьләрне яклау, тәҗрибә алмашу, иҗади конкурслар һәм проектлар күргәзмәләре уздыру. 2009 да берлектә 200 кеше әгъза булып тора. 2000 елларда ТР Архитекторлар берлеге җитәкчелегендә Колшәриф мәчете, Ф.Шаляпин, С.Сәйдәшев һәйкәлләре, Казан метрополитены станцияләрен бизәү, Казанның үзәк өлешен реконструкцияләү, элеккеге иске аэропортта яңа микрорайоннар һ.б. кору проектларына иҗади конкурслар; Казан Кремлен, Иске Татар бистәсен, Зөя шәһәрен саклау һәм үстерү концепциясен эшләү буенча фәнни конференцияләр үткәрелә. Архит-ра проектларына 20 дән артык күргәзмә оештырыла. 1970 тән Архитекторлар йортында урнашкан (к. *Чукашёв йорты*).

Идарә рәисләре: Г.П.Баранников (1934–36), В.П.Попов (1936–37), А.М.Власов (1937–38), М.М.Стрекалов (1938–39), Г.И.Спиридонов (1939–40), А.А.Трофимов (1940–41), Р.М.*Мортазин* (1941–43), И.А.Вәлиев (1943–44), С.С.Копец (1944–48), А.Э.*Спориус* (1948–58), П.А.Саначин (1958–62), М.Х.Агишев (1962–67), А.Г.*Бикчәнтәев* (1967–70), С.С.*Айдаров* (1970–88), И.Д.Галанин (1988–91), Ф.М.*Зәбирова* (1991–2000), Р.М.Нургалиева (2000–04), И.Ф.Сәйфуллин (2004–05), В.П.*Логинов* (2006–16).

*Л.Е.Спориус.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ӘЙЛӘНӘ́-ТИРӘ́ МОХИТНЕ́ ҺӘМ ТАБИГЫ́Й БАЙЛЫКЛАРНЫ́ САКЛА́У МИНИ́СТРЛЫГЫ**, ТАССР ЮС Президиумының 1988 ел 12 декабрь Указы нигезендә ТАССРның Табигатьне саклау Дәүләт ком-ты буларак оештырыла, ТР ЮСның 1992 ел 25 декабрь карары б-н хәзерге исемдәге ком-т итеп үзгәртелә. Әйләнә-тирә табигый мохитне саклау, табигый ресурсларны көйләү һәм алардан файдалану, аларның яңарып торуын һәм экологик яктан куркынычсызлыгын тәэмин итү б-н шөгыльләнә. Әйләнә-тирә мохитне саклау (атмосфера һавасын, су ресурсларын, җир ресурсларын саклау һәм калдыкларны утильләштерү, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы, әйләнә-тирә мохит мониторингы бүлекләре), дәүләт экология экспертизасы һәм табигатьтән файдалануны нормалаштыру (табигатьтән файдалану һәм табигый ресурсларны торгызу, табигый ресурслар икътисады һәм аларны планлаштыру бүлекләре), адм.-финанс (финанс, ревизия, норматив-хокукый көйләү бүлекләре, канцелярия, хуҗалык секторы) идарәләрен, радиоэкологик куркынычсызлык секторын, дәүләт төбәк инспекциясен (2 терр. идарә һәм 7 төбәк инспекциясе), кече елгаларның су ресурсларын саклау һәм торгызу, төп эшчәнлекне тәэмин итү, аналитик контроль (9 төбәк инспекциясе) махсус инспекцияләрен үз эченә ала. ТР Президентына, ТР МКна (1991 гә кадәр ТАССР, ТССР МСна), РФнең шундый ук министрлыгына буйсына. ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май карары б-н гамәлдән чыгарыла, вәкаләтләре *Татарстан Республикасы Экология и табигый байлыклар министрлыгына* тапшырыла.

Дәүләт ком-ты рәисе — А.А.Сидельников (1989–92), министр — А.И.Щеповских (1993–2001).

Ш.у.к. *Табигатьне саклау.*

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ БӘЯЛӘ́Р ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**, ТАССР ЮС Президиумының 1970 ел 5 февраль Указы нигезендә ТАССР МС каршындагы Бәяләр бүлеге буларак оештырыла, ТАССР ЮС Президиумының 1979 ел 22 август Указы б-н ТАССР (1992 дән — ТР) Бәяләр дәүләт ком-ты итеп үзгәртелә. Бәяләр һәм тарифлар өлкәсендә дәүләт сәясәтен уздыра. Секретариатны, бәяләр формалашу һәм җитештерү өлкәсе, җитештерү өлкәсендә бәяләр һәм тарифлар, җитештерүгә бәйле булмаган өлкәдәге бәяләргә һәм тарифларга контроль, Агросәнәгать комплексындагы һәм кооперация өлкәсендәге бәяләргә һәм тарифларга контроль, контрольлек эше методикасы һәм анализы бүлекләрен үз эченә ала. ТР Президентына, ТР МКна (1991 гә кадәр ТАССР, ТССР МСна) һәм РСФСРның шундый ук Дәүләт ком-тына буйсына. ТР ЮСның 1994 ел 8 февраль карары б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары *Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитетының* Бәяләр идарәсенә тапшырыла (1995 тән).

Рәисләр: Г.И.Петров (1979–87), Ф.Б.Баһаветдинов (1987–94).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ГАДӘТТӘ́Н ТЫШ ХӘЛЛӘ́Р МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ГИДРОМЕТЕОРОЛО́ГИЯ ҺӘМ ӘЙЛӘНӘ́-ТИРӘ́ МОХИ́Т МОНИТО́РИНГЫ ИДАРӘСЕ́**, табигый тирәлекнең торышы, атм. һавасы мониторингы, явым-төшемнәр, җир өсте сулары, радиация мониторингы буенча системалы рәвештә җентекле күзәтүләр алып баручы федераль дәүләт учреждениесе. Һава торышы фаразлары төзи, бәла-каза куркынычы б-н янаучы метеорологик күренешләр, ш.у. әйләнә-тирә мохитнең гадәттән тыш пычрануы турында кисәтә. Сәнәгать, а.х. һәм җылылык-энергетика комплексы пр-тиеләрен, коммуналь һәм юл хезмәте, төзелеш һәм транспорт компанияләре, елга флоты, иминият оешмалары, массакүләм мәгълүмат чараларын махсус гидрометеорологик мәгълүмат б-н тәэмин итә. 1930 елда ТАССР ХКС каршында Гидрометбюро ачыла һәм һава торышы турында беренче прогноз төзелә. 1964 тә — бюро Казан гидрометеорология обсерваториясе, 1988 дән — Татарстан гидрометеорология үзәге, 1992 дән — гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы үзәге; 1999 дан хәзерге исемендә.

Идарә составында: бүлекләр — метеорологик прогнозлар, метеорология, климат һәм авиацияне метеомәгълүмат б-н тәэмин итү, агрометеорология, гидрология; әйләнә-тирә мохит мониторингының комплекслы лаб-ясе; төркемнәр — метеорологик радиолокация күзәтүләре; аэрологик күзәтүләр; мәгълүматларны автоматлаштырылган тапшыру хезмәте. Дәүләт күзәтү челтәре карамагында: 13 метеорология станциясе (Азнакай, Акташ, Арча, Карамалы Тау, Чүпрәле, Алабуга, Казан-Опорная, Олы Кайбыч, Лаеш, Мөслим, Тәтеш, Чистай, Чулпан), 4 авиаметеорология станциясе (Бигеш, Бөгелмә, Казан-Сокол, Минзәлә), 3 метеорология һәм 4 агрометеорология посты, 19 елга һәм 12 күл гидрология посты, 9 атм. һавасы һ.б. пычрануны күзәтү посты.

Идарә җитәкчеләре арасында — П.Т.*Смоляков* (1930–33), Н.В.*Колобов* (1938–39), А.И.Мишкарёв (1948–81), А.П.Шлычков (1981–97), С.Д.Захаров (1999 дан).

*Әд.:* Гидрометслужба Республики Татарстан: пути становления и перспективы развития. СПб., 2000.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ГРАЖДАННА́Р ОБОРО́НАСЫ ҺӘМ ГАДӘТТӘ́Н ТЫШ ХӘЛЛӘ́Р МИНИ́СТРЛЫГЫ**, ТР Дәүләт Советының 1995 ел 22 июнь карары б-н ТРның Гадәттән тыш хәлләр Дәүләт ком-ты буларак оештырыла, ТР Дәүләт Советының 1995 ел 11 октябрь карары б-н — ТРның Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү Дәүләт ком-ты, ТР Дәүләт Советының 1996 ел 25 апрель карары б-н ТРның Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы итеп үзгәртелә, ТР Дәүләт Советының 1997 ел 19 июнь карары б-н хәзерге исемендә. Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм юкка чыгару, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә җитәкчелек итә. Эшләр башкару, финанс-икътисад идарәләрен; төбәк чикләрендә һәм муниципальара кысаларда гадәттән тыш хәлләр куркынычы ихти-




ТАССР Дәүләт гербы. 1937.




ТАССР Дәүләт гербы. 1978.




Татарстан Республикасы Дәүләт гербы. 1992.

маллыгы б-н идарә итү, гадәттән тыш хәлләр мониторингы һәм аларны фаразлау, перспективалы үсеш һәм тернәкләндерү, гражданнар оборонасы өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм юкка чыгару буенча терр. системаларның көндәлек эшчәнлеген һәм гамәлләрен оештыру, Министрлык эшчәнлеген планлаштыру һәм идарә итү, мәгълүмат, автоматлаштырылган идарә итү системалары, терр. хәбәрдарлык системаларын, идарә чараларын булдыру һәм аларны әзерлектә тоту, гомуми, адм.-хуҗалык, бухгалтерлык исәбе һәм хисап, методология һәм финанс анализы, хезмәт һәм хезмәт хакы, шартнамә-дәгъва белдерү эшчәнлеге һәм норматив хокукый актлар эшләү, кадрлар аудиты һәм персонал б-н идарә итү, вазифаи затлар әзерләү һәм халыкны өйрәтү, гаммәви мәгълүмат чаралары б-н эшләү, авария-коткару формированиеләрен оештыру, аттестацияләү һәм теркәү бүлекләрен; сер режимы, махсус элемтә секторларын үз эченә ала. Министрлык системасына шәһәр һәм район гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр идарәләре, Янгыннан саклану дәүләт хезмәте уку-укыту үзәге, Гражданнар оборонасы уку-методик үзәге, Респ-ка тернәкләндерү үзәге, Эзләү-коткару хезмәте, Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең җитештерү-техник үзәге, гражданнар оборонасы складлары керә. ТР Президентына, ТР Министрлар Кабинетына, РФнең шундый ук Министрлыгына буйсына.

Дәүләт ком-ты рәисе — В.А.Швецов (1995–96). Министрлар: В.А.Власов (1996–2007), Р.З.Хәбибуллин (2007 дән).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ДӘҮЛӘ́Т БҮЛӘКЛӘРЕ́**, Татарстан үсешенә өлеш керткән өчен бүләкләнгән затларның аеруча мөһим казанышлары дәүләт һәм җәмгыять тарафыннан танылуның иң югары чагылышы. ТРның 2004 ел 24 март, 2010 ел 31 декабрь, 2011 ел 10 октябрь, 2012 ел 11 июнь һәм 2015 ел 25 апрель Законнары б-н ТРның түбәндәге дәүләт бүләкләре гамәлгә кертелә: «*Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен*», «*Дуслык*» орденнары; «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале, «*Намуслы хезмәт өчен*» («Фидакарь хезмәт өчен»), «*Ана даны — Материнская слава*», «*Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен*», «*Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңае белән*» медальләре.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ДӘҮЛӘ́Т ГЕ́РБЫ**, ТР дәүләт хакимиятенең рәсми билгесе (*Татарстан Республикасы Дәүләт гимны*, *Татарстан Республикасы Дәүләт флагы* б-н беррәттән). ТАССРның 1937 елгы Конституциясе буенча респ-каның Дәүләт гербын башаклар б-н каймаланган кызыл җирлектәге кояш нурлары өстендә сапларын түбәнгә каратып чалыштырылган алтын урак һәм чүкечне сурәтләүче, рус һәм татар телләрендә «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» сүзләре урнаштырылган, «РСФСР» язуы астына кечерәк итеп татар телендә язылган «Татарстан АССР» сүзләре өстәлгән РСФСР Дәүләт гербы тәшкил итә. ТАССРның 1978 елгы Конституциясе кабул ителгәннән соң, респ-ка Дәүләт гербы өлешчә үзгәртелә: гербның өске өлешендә бишпочмаклы йолдыз барлыкка килә. 1992 нең 7 февралендә ТР ЮС ТРның яңа Дәүләт гербын раслый (авторлары — Н.Г.Ханзафаров, Р.З.Фәхретдинов; иҗат коллективы җитәкчесе — Р.М.Харисов). ТР Д.г.ның тасвирламасы ТРның 1992 елгы Конституциясендә теркәлә. ТР Д.г. кояш җирлегендә бер ягында түгәрәк калканлы, алгы тәпиен бераз күтәргән канатлы барс сурәтеннән гыйбарәт. Ул татар милли бизәкләре б-н уратып алынган, бизәкләрнең үзәк өлешенә «Татарстан» дип язылган. Гербның төсле күренешендә кояш — кызыл, барс — ак, тышкы кыса — яшел, кысадагы бизәк һәм язу алтынсу төстә. Биналар диварларына, дәүләт хакимияте органнарының, идарә һәм мәхкәмәнең утырышлар залларына, туу һәм никахлашучыларны теркәүче дәүләт учреждениеләре биналарында, рәсми мөһерләргә һәм документ кәгазьләренә, ТРның рәсми басмаларына урнаштырыла.

Чыг.: Харис Р. Татарстан символлары (татар, рус, инглиз телләрендә). К., 2005; Конституция (Основной Закон Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. К., 1937; Конституция (Основной Закон) Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. К., 1978; Конституция Республики Татарстан. К., 1992; Государственная символика Республики Татарстан. К., 1995.

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ДӘҮЛӘ́Т ГИ́МНЫ**, ТР дәүләт хакимиятенең рәсми билгесе (Татарстан Республикасы Дәүләт гербы, Татарстан Республикасы Дәүләт флагы б-н беррәттән). Муз. редакциясе композитор Р.М.Яхин музыкасы нигезендә (симф. оркестр өчен Р.К.Абдуллин эшкәртүендә) ТР ЮСның 1993 ел 14 июль карары б-н раслана. Гимн турындагы нигезләмә ТР МКның 1993 ел 27 август карары б-н раслана. Гимнның Р.Байтимеров сүзләренә язылган татарча һәм русча (русчага тәрҗемә итүче — Ф.Пираев) тексты ТРның 2013 ел 21 февраль законы б-н раслана. Тантаналы очракларда (бәйрәм чараларында, рәсми тантаналарда) башкарыла.

Мәңге яшә, газиз Ватаныбыз,
Халкым тели изге теләкләр!
Гомерлеккә якын туган булып
Яши бездә төрле милләтләр.
Күп гасырлар кичкән чал тарихлы
Данлы илем, үзең бер дастан!
Синдә генә безнең язмышыбыз,
Республикам минем, Татарстан!
Цвети, священная земля моя,
Да будет мирным твой небосвод!
Единый дом у нас, одна семья,
Живёт в согласии народ.
Богатый мудростью седых веков,
Надеждой, верою ты нам стал,
И пусть хранит тебя моя любовь,
Моя Республика, мой Татарстан!

Чыг.: Конституция Республики Татарстан. К., 1992; Государственная символика Республики Татарстан. К., 1995.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ДӘҮЛӘ́Т ИМИНЛЕГЕ́ КОМИТЕТЫ́**, респ-ка дәүләт хакимияте органы. Казан Эшче һәм солдат депутатлары советының 1917 ел 26 октябрь карары нигезендә Казан Вакытлы революцион штабының тикшерү комиссиясе буларак оештырыла. Казан Эшче һәм солдат депутатлары губерна советының 1917 ел 15 һәм 19 ноябрь карарлары б-н — шул ук Совет каршындагы мәхкәмә-тикшерү комиссиясе, Казан Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары губерна советының 1918 ел 27 февраль карары б-н — губерна советы каршындагы революцион-тикшерү комиссиясе дип үзгәртелә, Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советы Казан губерна башкарма




Татарстан Республикасы Дәүләт гимны. 1993.

ком-ты Президиумының 1918 ел 1 июль карары б-н Казан революцион трибуналы тикшерү комиссиясенең контррев-циягә каршы көрәш бүлеге (1917 нең 27 ноябрендә оештырыла) б-н берләштерелә һәм исеме Контррев-ция, спекуляция һәм саботажга каршы көрәш буенча Казан гадәттән тыш тикшерү комиссиясе дип алыштырыла, РСФСР ХКСның 1918 ел 16 июль Декреты б-н — Чех-словак фронтында Контррев-циягә каршы көрәш буенча гадәттән тыш комиссия, РКП(б) Казан губерна ком-тының 1918 ел 8 октябрь карары б-н — Контррев-ция, спекуляция һәм саботажга каршы көрәш буенча Казан губерна гадәттән тыш комиссиясе, БҮБК һәм РСФСР ХКСның 1920 ел 28 сентябрь карары б-н — ТАССР ХКС каршындагы Контррев-ция, спекуляция һәм вазифаи җинаятьләргә каршы көрәш буенча Бөтентатарстан гадәттән тыш комиссиясе, БҮБКның 1922 ел 6 февраль карары б-н — РСФСР Эчке эшләр халык комис-ты каршындагы Баш сәяси идарәнең (ГПУ) Татарстан сәяси бүлеге, СССР ҮБКның 1923 ел 2 ноябрь карары б-н — СССР ХКС каршындагы Берләштерелгән дәүләт сәяси идарәсенең (ОГПУның) Татарстан бүлеге, СССР ХКС каршындагы ОГПУның 1931 ел 11 август боерыгы б-н — СССР ХКС каршындагы ОГПУның Татарстан буенча тулы вәкаләтле вәкиллеге, СССР ҮБКның 1934 ел 10 июль карары б-н — СССР Эчке эшләр халык комис-тының ТАССР буенча идарәсе яшерен-сәяси бүлеге, ТАССР ҮБК Президиумының 1937 ел 20 март карары б-н — ТАССР Эчке эшләр халык комис-тының Дәүләт иминлеге идарәсе, ТАССР ЮС Президиумының 1941 ел 11 март һәм 1943 ел 12 июль Указлары б-н — ТАССР Дәүләт иминлеге халык комис-ты, ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы б-н — ТАССР Дәүләт иминлеге министрлыгы, РСФСР ЮС Президиумының 1953 ел 30 май Указы һәм ТАССР МСның 1953 ел 16 июнь карары б-н — ТАССР Эчке эшләр министрлыгы Дәүләт иминлеге идарәсе, ТАССР ЮС Президиумының 1954 ел 17 июнь Указы б-н ТАССР (1990 нан — ТССР, 1992 дән — ТР) Дәүләт иминлеге ком-ты (1978 гә кадәр — МС каршында) итеп үзгәртелә. Элек дәүләт иҗтимагый строен дошман дәүләтләрнең разведка һ.б. махсус хезмәтләре һәм ил эчендәге хөкем сөргән строй дошманнарының җимерү эшчәнлегеннән саклау б-н шөгыльләнә. РФнең 1992 ел 8 июль Законы буенча шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең иминлеген тәэмин итә; чит илләр махсус хезмәтләренең һәм оешмаларының разведка-җимерү эшчәнлеген, хокук бозып, илнең конституцион строена, суверенлыгына, терр. бөтенлегенә һәм оборона сәләтенә кул сузуларны ачыклау, искәртү һәм туктату юнәлешендә эш алып бара. Бөтенроссия Гадәттән тыш комиссиясенә (1922 гә кадәр), РСФСР Эчке эшләр халык комис-тына (1922–23), СССР ХКС каршындагы ОГПУга (1923–34), СССР Эчке эшләр халык комис-тына (1934–37), ТАССР Эчке эшләр халык комис-тына (Министрлыгына; 1941, 1943–53), СССР Эчке эшләр министрлыгына (1953–54), СССР Дәүләт иминлеге ком-тына (1954–91), РФ Иминлек министрлыгына (1992–93), РФ Федераль иминлек хезмәтенә (1995 тән), ТР Президентына, ТР МКна (1991 дән) буйсына. ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май карары б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары РФ Федераль иминлек хезмәтенең ТР буенча Идарәсенә тапшырыла.

Җитәкчеләре: Л.Р.Милх (1917–1918 нең февр.), Г.Ш.Олькеницкий (1918 нең февр.–июне), П.А.Кин (1918 нең июне–июле), М.Я.Лацис (1918 нең июле–окт.), К.М.Карлсон (1918 нең окт.–1919), Ж.Я.Девингталь (1919–20), Г.М.Иванов (1920–21), А.А.Денисов (1921–22), С.С.Шварц (1922–24), И.К.Даниловский (1924–25), И.А.Кадушкин (1925–27), Д.Я.Кандыбин (1927–32), Г.П.Матсон (1932–33), В.Н.Гарин (1933–36), П.Г.Рудь (1936–1937 нең июле), А.М.Алемасов (1937 нең июле–сент.), В.И.Михайлов (1937 нең сент.–1939), Е.М.Морозов (1939–43), А.Г. Габитов (1943–44), А.Ф.Ручкин (1944–47), Д.С.Токарев (1948–52), П.П.Семёнов (1953–57), П.И.Ромашков (1957–61), А.Х.Бичурин (1961–80), И.Х.Галиев (1980–87), Р.Г.Кәлимуллин (1987–93), В.А.Сәлимов (1993–99), А.П.Гусев (1999– 2001).

Чыг.: Упрочение Советской власти в Татарии (октябрь 1917 – июль 1918 гг.): Сб. док. и материалов. К., 1964; Казанская губернская Чрезвычайная комиссия 1917–1922 гг.: Сб. док. и материалов. К., 1989.

*Әд.:* История советских органов государственной безопасности. М., 1977; Защищая революцию: Чекисты Татарии в первые годы Советской власти 1917–1922. К., 1980; Российские спецслужбы: история и современность. М., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЛАРЫ́**, дәүләтнең тармакара идарә респ-ка органнары. 1970 елларда халык хуҗалыгы б-н җитәкчелек итүдә туган җитди кыенлыклар сәбәпле барлыкка киләләр. Барлык тармаклар яки тармак төркемнәренә караган пр-тиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар эшчәнлеген координацияләү, көйләү һәм контрольдә тоту б-н шөгыльләнәләр, тармакара дәүләт идарәсе мәсьәләләрен фәнни яктан эшләүне тәэмин итәләр. Аларның төп вазифалары һәм вәкаләтләре респ-ка хөкүмәте тарафыннан расланган аерым дәүләт ком-тлары турындагы нигезләмәләр б-н билгеләнә. Яңа дәүләт ком-тларын оештыру, булганнарын гамәлдән чыгару ТР Дәүләт Советы (1995 кә кадәр ЮС) тарафыннан гамәлгә ашырыла. Дәүләт комитетларының эшчәнлеген ТР МК (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР МС) көйли. ТР Президен-

тына һәм ТР Хөкүмәтенә буйсыналар. ТР Президенты тарафыннан (2002 гә кадәр ТР Дәүләт Советы, элегрәк — ТАССР, ТССР МС Рәисе тәкъдиме ЮС б-н килештерелеп) билгеләнүче һәм вазифаларыннан азат ителүче рәисләр җитәкли. Татарстанда төрле елларда эшләгән һәм хәзерге вакытта гамәлдәге дәүләт комитетлары: Авыл хуҗалыгын житештерү техникасы б-н тәэмин итү (1978–85), Балалар һәм яшьләр эшләре (1993–2001), Бәяләр (1979–94), Геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану (1996–2001); Дәүләт иминлеге (1954–2001), Дәүләт милкәте б-н идарә итү (1991–2001), Дәүләт милкәтен хосусыйлаштыру (1995–96), Җир ресурслары һәм җир реформасы (1991–2001), Икътисад һәм фаразлау (1991–96), Кинематография (1993–2001), Кинофикация (1979–88), Кулланучылар хокукларын яклау (1995–2001), Матбугат, полиграфия һәм китап сәүдәсе (1979–91), Матди-техник тәэминат (1979–91), Сан.-эпид. күзәтчелеге (1991–2001), Сатып алулар (2014 тән), Статистика (1992–2002), Табигатьне саклау (1988–92), Тарифлар (2010 нан), Телевидение һәм радиотапшырулар (1982–92), Төзелеш һәм архит-ра (1979–96), Туризм (2014 тән), Физик культура, спорт һәм туризм (1986–2001), Хезмәт һәм мәшгульлек (1979–2001), Һөнәри-техник белем бирү (1987 — 88) ком-тлары.

*Әд.:* Долгов Е.Б. Государственные комитеты как органы исполнительной власти Республики Татарстан: История и современность // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003. *Е.Б.Долгов, Р.И.Тарнопольский.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ДӘҮЛӘ́Т СОВЕТЫ́** (парламент), ТР дәүләт хакимиятенең даими эшләүче иң югары вәкиллекле һәм закон чыгару органы (Татарстан Республикасы Югары Советы дәвамчысы). Беренче тапкыр 1995 елда сайлана. Бер палаталы, гомуми, тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү юлы б-н 5 елга сайланган 100 (2004 кә кадәр — 130) халык депутатыннан тора. Дәүләт Советы вәкаләтләренә ТР Конституциясен кабул итү һәм аңа үзгәрешләр кертү; законнар кабул итү һәм аларга аңлатмалар бирү; эчке сәясәтне һәм тышкы эшчәнлек юнәлешләрен билгеләүдә катнашу; бюджетны, социаль-икътисади үсеш программаларын раслау һәм аларның үтәлешен контрольдә тоту; респ-ка милке б-н идарә итү тәртибен гамәлгә ашыру; респ-ка һәм җирле хакимиятләр һәм идарә органнарын булдыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибен оештыру; сайлаулар һәм референдумнар билгеләү; адм.-терр. төзелешне раслау; чикләрне үзгәртү; дәүләт бүләкләрен гамәлгә кую һәм мактаулы исемнәрне билгеләү керә. Респ-ка Дәүләт Советы ТР Премьер-министрын (ТР Президенты тәкъдиме буенча) раслый, ТР Конституция мәхкәмәсен, җәмәгать судьяларын, ТРда Кеше хокукларын яклау буенча вәкил сайлый, ТР Прокуроры вазифасына кандидатураны килештерә, ТР Президентына, ТР Премьер-министрына һәм аның урынбасарларына ышанычсызлык белдерә һ.б. ТР Д.С. рәисен, рәис урынбасарларын, ТР Д.С. секретарен, ТР Д.С. Президиумын сайлый; Дәүләт Советы ком-тларын һәм Хисап палатасын оештыра. ТР Д.С.ның төп актлары — законнар, карарлар.

Респ-ка Дәүләт Советы Рәисе Дәүләт Советы, аның утырышлары б-н җитәкчелек итә, парламент эшен оештыра, ТР Конституциясендә һәм законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкара.

Респ-ка Дәүләт Советы Президиумы Дәүләт Советы эшен оештыруны тәэмин итә, үз карамагындагы мәсьәләләр буенча карарлар чыгара.

ТР Д.С.ның Дәүләт төзелеше һәм җирле үзидарә; Законлылык, хокук тәртибе; Бюджет, салымнар һәм финанс; Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек; Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр; Социаль сәясәт; Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр ком-тлары эшли.

Төп басмасы — «Ведомости Государственного Совета Республики Татарстан» (1995 тән).

Рәисләр: В.Н.Лихачёв (1995–98), Ф.Х.Мөхәммәтшин (1998 дән).

Чыг.: Закон Республики Татарстан «О внесении изменений и дополнений в Конституцию Республики Татарстан» от 19 апреля 2002 года // Республика Татарстан. 2002. 30 апр.

*Б.Л.Железнов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ДӘҮЛӘ́Т ТЕЛЛӘРЕ́**, рәсми органнар, вазифаи затлар һәм гражданнар тарафыннан законнар чыгару, мәхкәмә гамәлендә, эшлекле аралашу һәм укыту өлкәләрендә кулланылучы телләр. Бу юнәлештә беренче адымнар Татарстан АССР төзелгәннән соң (1920) ясала. Рәсми эш кәгазьләрен алып баруда рус теле б-н беррәттән татар теле дә кулланыла башлый (к. *Татар телен гамәлгә кертү комиссиясе*). ТРның 1992 елгы Конституциясе һәм ТРның «Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында» 1992 ел 8 июль Законы тарафыннан ТР Д.т. сыйфатында тигез хокуклы татар һәм рус телләре билгеләнә, ш.у. респ-када яшәүче барлык халыкларның телләрен саклау гарантияләнә һәм тәэмин ителә. Һөнәр буенча һәм тел принцибы буенча чикләүне кертеп, тел принцибы буенча кыерсыту тыела. ТР ЮСның 1994 ел 20 июль, 2014 ел 30 май, 2015 ел 1 апрель һәм 7 ноябрь карарлары б-н ТР халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт программасы раслана.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ДӘҮЛӘ́Т ФЛАГЫ́**, ТР дәүләт хакимиятенең рәсми билгесе (*Татарстан Республикасы дәүләт гербы, Татарстан Республикасы дәүләт гимны* б-н беррәттән). ТАССРның 1937 елгы Конституциясе буенча респ-каның Дәүләт флагы булып флаг сабы кырыендагы сул як-тагы өске почмагында алтын хәрефләр б-н язылган рус һәм татар телләрендәге «РСФСР» язуы астына кечерәк итеп рус һәм татар телләрендәге «Татарстан АССР» сүзләре өстәлгән кызыл төстәге тукымадан гыйбарәт РСФСР Дәүләт флагы исәпләнгән. ТАССРның 1954 ел 23 июнь Законы б-н респ-ка Дәүләт флагы өлешчә үзгәртелә һәм РСФСРның флаг сабы кырыенда флаг озынлыгының 1/8 өлешен тәшкил иткән киңлеге буенча сузылган ачык зәңгәр төстәге буй урнашкан турыпочмаклы кызыл тукыма рәвешендәге Дәүләт флагыннан гыйбарәт була. Кызыл тукыманың сул яктагы өске почмагында алтын урак һәм чүкеч, алар өстендә алтын кайма б-н чикләнгән бишпочмаклы йолдыз, урак һәм чүкеч сурәтләре астында, алтын хәрефләрдән җыелган «Татарская АССР» язуы урын алган. Әлеге тасвирлама




ТАССР Дәүләт флагы. 1937.



ТАССР Дәүләт флагы. 1954.



Татарстан Республикасы Дәүләт флагы. 1991.

ТАССРның 1978 елгы Конституциясендә дә саклана. 1991 нең 29 ноябрендә ТССР ЮС Татарстанның яңа Дәүләт флагын раслый (авторы — Т.Г.Хаҗиәхмәтов, иҗат коллективы җитәкчесе — Р.М.Харисов). ТРның 1992 елгы Конституциясендә теркәлгәнчә, ТР Д.ф. горизонталь яшел, ак һәм кызыл төстәге буйлардан торган турыпочмаклы тукымадан гыйбарәт. Ак төстәге буй флаг киңлегенең 1/15 өлешен тәшкил итә, ул тигез киңлектәге яшел һәм кызыл төстәге буйлар уртасында урнашкан. Яшел буй — флагның өске өлешендә, флагның киңлеге аның озынлыгына карата 1:2 нисбәтендә. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары (даими рәвештә), җәмәгать оешмалары, пр-тиеләр, учреждениеләр биналары, ш.у. торак йортлар өстендә, елга флоты судноларында һ.б. юл йөрү чараларында, тантаналар һәм бәйрәм көннәрендә урнаштырыла.

Чыг. к. *Татарстан Республикасы дәүләт гербы* мәкаләсен. *Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ДИН ЭШЛӘРЕ́ СОВЕТЫ́**, Татарстан Респ-касы МК каршында, ТР дәүләт идарәсе органы. Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы Казан губерна башкарма ком-ты юстиция бүлегенең 1919 ел 22 ноябрь күрсәтмәсе б-н чиркәүне дәүләттән аеру турындагы Декретны гамәлгә ашыру комиссиясе буларак оештырыла; ТАССР ҮБКның 1920 ел 28 сентябрь карары б-н ТАССР Юстиция халык комис-тының чиркәүне дәүләттән аеру бүлеге итеп үзгәртелә (1931 гә кадәр эшли). 1930 еллар — 1940 еллар башында дингә карата дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру ТАССР ҮБК каршындагы дин эшләре мәсьәләләре буенча даими комиссиягә (Бөтенроссия ҮБК Президиумының 1931 ел 30 май карары б-н оештырыла; 1938 гә кадәр эшли), аннары ТАССР ЮС Президиумы каршындагы шундый ук комиссиягә (1938–43) йөкләнә. Соңрак СССР ХКСның 1943 ел 18 декабрь һәм 1944 ел 19 май карарлары нигезендә СССР ХКС (1946 дан — МС) каршындагы Рус православие чиркәве эшләре советының ТАССР буенча вәкиле һәм СССР ХКС (1946 дан — МС) каршындагы Дин эшләре советының ТАССР буенча вәкиле вазифалары булдырыла; алар СССР МСның 1965 ел 8 декабрь карары б-н гамәлдән чыгарыла һәм СССР МС каршындагы Дин эшләре советының ТАССР буенча вәкиле вазифасы (1991 гә кадәр) кертелә. Әлеге органнар дин эшләре турындагы законнарның үтәлешен контрольдә тоту, дини берләшмәләрне исәпкә алу, дәүләт структуралары һәм дини общиналар арасында багланышларны җайга салу б-н шөгыльләнәләр. ТССР МСның 1991 ел 3 июнь карары б-н ТССР (1992 дән — ТР) МС (МК) каршындагы Дин эшләре советы оештырыла. Совет дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны контрольдә тота, вөҗдан иреге һәм дин тоту ирекге мәсьәләсендә кеше һәм гражданлык хокуклары, дәүләт-конфессиональ һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләр өлкәләрендә дәүләт идарәсе органнары эшчәнлеген координацияли. ТР Президентының 2008 ел 20 август Указы б-н ТР МК каршындагы Дин эшләре идарәсе, 2010 ел 27 декабрь Указы б-н ТР Президентының Дини берләшмәләр б-н үзара хезмәттәшлек идарәсе итеп үзгәртелә.

Вәкилләр: Ф.Ф.Горбачёв (1944–49, православие чиркәве эшләре буенча), Х.С.Багаев (1944–49, дини культлар эшләре буенча), Г.С.Сафин (1949–60), Ф.С.Мангуткин (1960–65), И.А.Михалёв (1965–84), И.Ш.Әүхәдиев (1984–86), С.Г.Гарипов (1986–88), И.Ш.Хәбибуллин (1989–91).

Рәисләр: И.Ш.Хәбибуллин (1991–97), Р.Ә.Нәбиев (1997–2007), Р.Н.Вәлиуллин (2007–08).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ИКЪТИСА́Д МИНИ́СТРЛЫГЫ**, тарихы Икътисад киңәшмәсе (ЭКОСО) каршында Дәүләт план комиссиясе (РСФСР ХКСның 1921 ел 17 март Декреты һәм ТАССР ХКСның 1922 ел 2 апрель карары нигезендә төзелә) оештырылган вакыттан башлана; 1926 дан ТАССР ХКС, 1946 дан ТАССР МС каршында эшли, ТАССР ЮС Президиумының 1978 ел 15 сентябрь Указы б-н исеме ТАССР Дәүләт план ком-ты (Госплан) дип үзгәртелә. Элек Татарстан халык хуҗалыгының гомуми үсеш планын эшләү һәм аны респ-каның төрле ведомстволарының план фаразларына яраклаштыру б-н шөгыльләнә. 1920 еллар уртасыннан ТАССР халык хуҗалыгының перспектив планын булдыру өстендә эшли һәм аны гамәлгә ашыру өчен чаралар системасын әзерли, респ-каның еллык бюджет проектларын, табигый байлыклардан файдалану, сәнәгатьне, а.х.н һ.б. тармакларны үстерү буенча планлаштыру-хуҗалык мәсьәләләрен карый; 1930 еллардан аңа халык хуҗалыгының тармаклар һәм районнар кысаларында еллык һәм квартал үсеш планнары проектларын, хәрби продукция, халык куллануы товарлары җитештерү өчен капитал кертүләрне, сәнәгать куәтләрен, җирле чималны, табигать байлыкларын рациональ файдалану мәсьәләләрен эшләү һ.б. йөкләнә; 1940–80 елларда Татарстан халык хуҗалыгы үсешен гомуми планлаштыруны һәм халык хуҗалыгы планнарының үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра. ТАССР Госпланы структурасында күп кенә үзгәрешләр була. 1920 елларда ул гомуми бүлекне, катнаш планлаштыру, сәнәгать, а.х., урман хуҗалыгы, транспорт һәм элемтә, ягулык һәм энергетика, сәүдә һәм тәэминат, мәдәният һәм сәламәтлек саклау, коммуналь хуҗалык, кооперация-сәүдә, капиталь төзелеш, финанс-бюджет секторларын; 1930 еллардан — эшләр башкару идарәсен, катнаш планлаштыру, район планы, капиталь төзелеш һәм матди-техник тәэминат, энергетика һәм ягулык, сәнәгать, урман, а.х., мәдәният һәм сәламәтлек саклау, товарлар әйләнеше һәм хәзерләүләр, торак-коммуналь хуҗалык, юл-транспорт хуҗалыгы һәм элемтә секторларын; 1980 елларда — катнаш комплекслы планлаштыру һәм планлаштыру эшен оештыру, сәнәгатьне, капиталь төзелешне, сәүдәне һәм товарлар әйләнешен, а.х.н һәм хәзерләүләрне, матди балансларны планлаштыру, җитештерү көчләрен урнаштыру, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү, халык куллануы товарларын җитештерү, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният һәм кадрлар әзерләү, халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтү, кадрлар бүлекләрен, бухгалтерияне үз эченә ала.

ТССР ЮСның 1991 ел 7 февраль карары б-н ТССР Дәүләт план ком-ты — ТССР (1991 дән — ТР) Икътисад һәм фаразлау дәүләт ком-ты, ТР Дәүләт Советының 1996 ел 25 апрель карары б-н — ТР И.м., ТР Дәүләт Советының 1998 ел 27 май карары б-н — ТР Икътисад һәм сәнәгать министрлыгы, ТР Президентының 2007 ел 10 июль Указы б-н кабат ТР И.м. итеп үзгәртелә. Министрлык Татарстанның икътисади үсеше б-н идарә итү буенча дәүләт сәясәтен булдыру б-н шөгыльләнә. Аның составына 20 йөз ахырында — социаль программалаштыру, идарә технологияләре, терр. үсеш, мәгълүмат сәясәте, кадрлар сәясәте, халык хуҗалыгы тармакларын икътисади анализлау, җитештерү-хуҗалык эшчәнлегенә аудит, машина төзелеше комплексы, оборона-сәнәгать комплексы, фәнни-тикшеренү ин-тлары һәм конструкторлык бюролары, сәнәгать б-н тармакларга бүлеп идарә итү, икътисади программалаштыру, индикатив идарә һәм тармакара баланс, икътисади анализ һәм финанс сәясәте, лицензияләү методологиясе, мәгълүматлаштыру, энергетика комплексы һәм энергия саклау, тарифлар сәясәте, нефть чыгару, химия һәм нефть химиясе, инвестицияләр һәм инновацияләр сәясәте, инфраструктуралар үсеше, федераль дәрәҗәдә рациональ программалаштыру, юридик, исәп һәм хисап, кадрлар, оештыру эше, гомуми, эш кәгазьләре бүлекләре; 2007 дән социаль-икътисади үсеш, терр. үсеш, адм. реформалар мәсьәләләре, инфраструктуралар үсеше, инвестицион инновацион эшчәнлек, эшләрне оештыру идарәләре, юридик, финанс һәм хисап, икенче, кадрлар, лицензияләү, тарифлар сәясәте, дәүләт инвестиция ресурслары бүлекләре керә. ТР Президентына һәм ТР МКна буйсына.

Госплан рәисләре: К.Г.Мохтаров (1922–23), А.В.Недачин (1923–1924 нең апр.), А.Н.Злобин (1924 нең апр.–окт.), Х.З.Габидуллин (1924 нең нояб.–1926), М.А.Эглит (1926–28), В.М.Горин (1928–30), А.Пусеп (1930–31), Д.С.Белик (1931–32), А.А.Терский (1932–34), С.З.Эскин (1934–35), Я.Ф.Ефимов (1935–37), В.Ф.Попов (1937–38), В.Е.Быстров (1938–40), П.П.Цыбин (1940–44), А.А.Полянский (1944–60), М.С.Соколов (1960–66), Ф.Т.Кунчий (1966–70), В.В.Сластников (1972–72), В.В.Ермаков (1972–88), Ю.М.Воронин (1988–90), Ф.Г.Хәмидуллин (1990–91).

Дәүләт ком-ты рәисләре: Ф.Г.Хәмидуллин (1992–95), А.М.Габетдинова (1995–96).

Министрлар: Д.М.Бикбов (1996–98), Р.Ш.Гобәйдуллин (1998–99), С.А.Когогин (1999–2002), А.М.Пахомов (2002–05), Б.П.Павлов (2005–07), М.Р.Сафиуллин (2007–10), М.Р.Шаһиәхмәтов (2010–14), А.А.Здунов (2014 тән).

Ш.у.к. *Сәнәгать.*

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ИКЪТИСА́Д ҺӘМ СӘНӘГА́ТЬ МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ КИНЕМАТОГРАФИСТЛА́Р БЕРЛЕГЕ́** (ТР КБ), Татарстан кино хезмәткәрләренең иҗтимагый оешмасы. СССР Кинематографистлар берлеге идарәсе секретариатының 1980 ел 25 декабрь һәм КПСС Татарстан өлкә ком-ты бюросының 1981 ел 21 гыйнвар карары нигезендә 1981 елның апрелендә ТАССР кинематографистларының 1 нче съездында ТАССР (1991 дән — ТР) КБ буларак оеша. Моңа кадәр Татарстан кинематографистлары СССР Кинематографистлар берлегенең Идел буе бүлеге әгъзалары булалар. 1990 да СССР Кинематографистлар берлеге ТАССР КБ статусын раслый, ул СССР КБ съездларында хәлиткеч тавыш хокукына ия була. ТР кинематографистлар съезды КБ идарәсенең югары органы булып тора, съездлар арасында җитәкчелек КБ съездында сайлап куелган идарә тарафыннан тормышка ашырыла. КБ идарәсенең беренче рәисе — И.Н.Алексеев, аннан

соңгы елларда — Х.Ф.Фәхретдинов, Н.К.Вәлитов, Р.И.Копосов, 2002 дән — Ю.К.Гвоздь, 2008 дән — И.З.Матуров, 2015 тән — И.Р.Ягъфәров. Берлек әгъзаларының проф. һәм идея-теоретик дәрәҗәләрен үстерү максатыннан кино һәм телевидениедә эшләүче яшь хезмәткәрләр өчен ел саен кинодокументалистларның иҗади конференцияләре, әйдәп баручы режиссёрлар һәм операторлар тарафыннан мастер-класслар, ТРда кино көннәре, иҗади конкурслар, кино фестивальләре һ.б. уздырыла. ТР КБ каршында төрле елларда «Таткиноүзәк», «Таткиновидеоүзәк» иҗат берләшмәләре, «Мизгел» документаль фильмнар студиясе эшли. 1991 дән ТР КБ составында оркестр (ТРның Дәүләт кинематография оркестры) эшли башлый. 2014 кә КБ составында — 39 кеше, ш.и. РСФСРның халык артистлары Р.А.Таҗетдинов, Р.Ш.Шәрәфиев, РФ, ТРның атказ. сәнгать эшлеклеләре В.И.Беспалов, Ю.К.Гвоздь, В.И.Севастьянов һ.б.

*Е.П.Алексеева.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ КИТА́П ПАЛА́ТАСЫ**, ТРда нәшер ителгән китапларның тулы библиографиясен булдыру, аларны исәпкә алу, теркәп бару, мәгълүмат тарату эшен башкара торган гыйльми үзәк. «ТАССРның Китап палатасы турындагы нигезләмә» 1926 елның 21 декабрендә ТАССР хөкүмәте карары б-н раслана. Китап палатасы оештырылу б-н, ТАССРда нәшер ителгән барлык басма әсәрләрнең дәүләт теркәве узуына һәм татар телендә библиографик күрсәткечләр чыгарыла башлауга нигез салына. Үз атамасын саклаган хәлдә, ул 1929 да — Татреспублика Фәнни китапханәсе бүлеге, 1932 дән Казан ун-ты китапханәсе бүлеге була. 1938 дән мөстәкыйль оешма буларак эшли башлый.

ТАССР ХКС карары нигезендә, 1927 нең 27 сентябреннән респ-каның барлык басмаханәләре дә үз продукциясенең мәҗбүри экземплярын Китап палатасына тапшырырга тиеш була. Хәзерге вакытта дәүләт матбугат архивында барлык төр басмаларның якынча 2,5 млн. данәсе саклана. Китап палатасының төп бурычы — агымдагы, ретроспектив (билгеле бер чорга караган) һәм укырга тәкъдим ителүче әдәбият библиографик күрсәткечләре төзү юлы б-н китапханәләргә һәм халыкка дөнья күргән басмалар турындагы мәгълүмат җиткерү. Китап палатасы тарафыннан нәшер ителүче «Татарстан Республикасының матбугат елъязмасы» басма продукция турындагы агымдагы мәгълүмат күрсәткече булып тора. Татар һәм рус телләрендә чыгарылган китаплар турында 1917–80 елларга (рус телендәге китаплар турында 1918–80 еллар) караган мәгълүматлар тупланган «Татарстан китаплары» библиографик җыентыгы иң әһәмиятле ретроспектив күрсәткечләрдән санала. 2010 да 6 томы басыла. 6 нчы томга 1981–2015 тә татар телендә басылган китаплар кертелә. Хәзерге көнгә ТР К.п. дәүләт матбугат архивын оештыру һәм эшчәнлеген тәэмин итү, ТРда нәшер ителгән басмаларның тулы җыелмасын туплау, милли библиографик репертуар төзү, мәгълүматларны эшкәртүдә автоматлаштырылган компьютер системасын кертү кебек вазифалар башкара. 2007 дән ТР Дәүләт матбугат архивы, ТР МКның Баш архив идарәсе карамагында.

*Әд.:* А ш м а с о в Г. Выставка произведений печати Книжной палаты за 1928 г. К., 1929; 50 лет Государственной книжной палате Татарской АССР. К., 1976; Культурное строительство в Татарии (1941–1970). К., 1976; Печать, радиовещание и телевидение Татарии: 1917–1980: Сб. док. и материалов. К., 1981.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ КОНСТИТУ́ЦИЯ МӘХКӘМӘСЕ́**, ТРның Татарстан Республикасы Конституциясе үтәлешен тикшерү йөкләнгән махсус мәхкәмә органы. ТРның 1992 ел 22 декабрь Законы нигезендә гамәлгә куела һәм ТР Дәүләт Советының 2000 ел 29 июнь карары б-н оештырыла. Рәистән, рәис урынбасарыннан һәм 4 мәхкәмә әгъзасыннан тора. ТР К.м. судьялары ТР Дәүләт Советы тарафыннан 10 елга сайланалар һәм фәкать законга гына буйсыналар. ТР К.м. ТР законнарының, ТР дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларының, ТРның халыкара һәм тышкы икътисади багланышларына кагылышлы, гамәлгә кермәгән килешүләренең Конституциягә туры килүен, ТР дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасындагы бәхәсләрнең вәкаләтлелеген карый, ТР Конституциясенә аңлатма бирә. Конституциягә туры килми дип табылган актлар һәм аларның аерым өлешләре ТР К.м. карарлары басылып чыккан көннән көчен югалта. ТР К.м. тарафыннан чыгарылган нәтиҗәләр соңгы карарлар дәрәҗәсендә була, протестлар һәм шикаятьләр кабул ителми.

Рәисләр: С.Х.Нәфиев (2000–04), В.Н.Демидов (2004–14), Ф.Г.Хәснетдинов (2014 тән).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ КОНСТИТУ́ЦИЯСЕ**, ТРның җәмгыять һәм дәүләт төзелешен, сайлау системасын, хакимиятнең вәкаләтле органнарын оештыру тәртибен һәм принципларын, гражданнарның бурычларын һәм хокукларын билгеләүче төп закон. ТАССР Конституциясе проекты 1925 елның 25 июнендә ТАССР ҮБКның 2 нче сессиясендә кабул ителә һәм 1926 ның 13 мартында ТАССР Советларының 6 нчы съездында хуплана. ТАССР Конституциясе проектын раслау БҮБК һәм Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советының Бөтенроссия съезды тарафыннан кире кагылса да, ул татар автономияле дәүләтчелеге оешу барышына йогынты ясый .

1930 елларның 2 нче яртысында СССР (1936) һәм РСФСР (1937) Конституцияләре нигезендә ТАССР Конституциясе эшләнә, 1937 нең 25 июнендә ТАССР Советларының 11 нче Гадәттән тыш съездында кабул ителә һәм шул ук елны РСФСР ЮС тарафыннан раслана. ТАССР Конституциясе тексты (1937) 11 бүлеккә берләштерелгән 114 маддәдән тора. 1 нче бүлектә Татарстан АССРның эшче һәм крәстияннәр соц. дәүләте булуы раслана, иҗтимагый стройның төп үзенчәлекләре билгеләнә: соц. хуҗалык системасы, җитештерү коралларына һәм чараларына дәүләт милке (бөтен халык милке) һәм кооперация-колхоз милке формасындагы соц. милек итеп карау; хезмәтне эшкә яраклы һәр гражданның бурычы һәм намус эше буларак карау; «кем эшләми — шул ашамый», «һәркемнән сәләтенчә — һәркемгә хезмәтенчә» принцибын тормышка ашыру. Җир, җир асты байлыклары, сулар, урманнар , пр-тиеләр, транспорт, банклар, элемтә чаралары, совхозлар, МТС, коммуналь пр-тиеләр һәм төп торак фонды дәүләт милкенә керә; колхозлардагы һәм кооперация оешмаларындагы җәмгать пр-тиеләре, алар җитештерә торган продукция, аларның җәмгать биналары кооперация оешмалары һәм колхоз милке булып исәпләнә. Колхозлар били торган җир аларга түләүсез һәм сроксыз файдалануга, ягъни мәңгегә беркетелә. Һәрбер колхозчы йортының үз файдалануында йорт тирәсендәге участокта үз милке: ярдәмче хуҗалыгы, торак йорты, терлекләре, йорт кошлары һәм вак а.х. инвентаре була. Ялгыз крәстияннәрнең һәм вак һөнәрчеләрнең шәхси хезмәткә нигезләнгән вак хосусый хуҗалыгы булуга закон тарафыннан юл куела. ТАССР Конституциясе (1937) гражданнарның хезмәт нигезендә ирешелгән керемнәре һәм җыелган акчаларына, йорт кирәк-яракларына, шәхси куллану әйберләре һәм җайланмаларга шәхси милек хокукын саклый. ТАССРда барлык хакимият респ-каның сәяси нигезен тәшкил иткән хезмәт ияләре депутатлары советлары аркылы шәһәр һәм авыл эшчәннәренә карый дип игълан ителә. 2 нче бүлектә ТАССРның дәүләт төзелеше расланып, Татарстан АССРның РСФСР составына автономияле респ-ка хокукында керүе билгеләнә. ТАССР терр-ясендә СССР һәм РСФСР законнары мәҗбүри була, ә ТАССРның һәрбер гражданы РСФСР һәм СССР гражданы булып тора. Үзенең югары дәүләт хакимияте һәм дәүләт идарәсе органнары йөзендә ТАССР вәкаләтләренә: респ-ка Конституциясен раслау, аны РСФСР ЮС раславына кертү һәм үтәлешенә күзәтчелек итү; районнарга бүленешне раслау һәм РСФСР раславына кертү; респ-ка законнарын чыгару; дәүләт тәртибен һәм гражданнарның хокукын саклау; респ-каның халык хуҗалыгы планын һәм бюджетын раслау; дәүләт салымнарын, җирле салымнарны, җыемнарны һәм салымнан тыш керемнәрне билгеләү; район, шәһәр һәм авыл советларының бюджетлары үтәлешенә җитәкчелек итү; иминият һәм саклык эшенә җитәкчелек итү; респ-ка буйсынуындагы сәнәгать, а.х., сәүдә пр-тиеләре һәм оешмалары б-н идарә итү; ш.у. җирле сәнәгатькә җитәкчелек итү; СССР һәм РСФСР органнары буйсынуындагы пр-тиеләрнең торышына һәм идарә ителешенә контроль һәм күзәтчелек итү; җирдән, җир асты байлыкларыннан, урманнардан һәм сулардан файдалану тәртибенә җитәкчелек итү һәм контрольдә тоту; шәһәрләрнең һәм халык урнашкан башка урыннарның торак-коммуналь хуҗалыгына, торак төзелешенә, төзекләндерү эшләренә җитәкчелек итү; юл төзелеше; сәламәтлек саклау, социаль тәэминат, халык мәгарифе, физик культура һәм спорт, мәдәни агарту, фән оешмалары һәм учреждениеләренә җитәкчелек итү; мәхкәмә органнарын оештыру керә. 3–7 бүлекләрдә дәүләт хакимияте һәм

дәүләт идарәсенең югары һәм җирле органнарын (ТАССР ЮС, ТАССР хөкүмәте, хезмәт ияләре депутатларының район, шәһәр, шәһәр районнары, посёлок һәм авыл советлары, ТАССР халык комис-тлары), мәхкәмә һәм прокуратура органнарын оештыру һәм эш принциплары, компетенциясе билгеләнә. ТАССР ЮСның вәкаләт чоры — 4, җирле советларныкы — 2 ел. 8 нче бүлектә гражданнарның нинди милләт һәм расадан, җенестән булуларына карамастан, дәүләт тарафыннан тигез хокуклы булулары гына түгел, ш.у. сәяси ирекләр: вөҗдан иреге, сүз иреге, матбугат иреге, җыелышлар һәм митинглар иреге, урамда оешып йөрү һәм демонстрацияләр иреге, җәмәгать оешмаларына берләшү иреге, шәхес һәм торак иминлеге, язышу сере саклану игълан ителә. Бу бүлектә гражданнарның социаль-икътисади — хезмәткә, ялга, белем алуга, картлыкта, авырганда һәм хезмәткә яраклылыкны югалтканда матди тәэмин ителүгә хокуклары билгеләнә. Гражданнарның хокукларын тормышка ашыру хезмәт ияләренең мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм соц. стройны ныгытуга юнәлдерелә. Гражданнарның бурычлары: Конституцияне, законнарны үтәү, хезмәт дисциплинасын саклау, җәмәгать бурычына намус б-н карау, соц. тормыш кагыйдәләренә хөрмәт б-н карау, соц. милекне саклау һәм ныгыту да шул ук максатларга хезмәт итәргә тиеш була. ТАССР Конституциясе (1937) гомуми хәрби хезмәт бурычынраслый, Кораллы Көчләр сафларында хезмәт итү гражданнарның мактаулы бурычы дип игълан итә. 93 нче маддә Коммунистлар партиясен Совет җәмгыятендә җитәкче үзәк сыйфатында беркетә. 9 нчы бүлектә ТАССРның сайлау системасы билгеләнә, барлык дәүләт хакимияте органнарының түбәннән югарыга кадәр гомуми, тигез һәм туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү тәртибендә сайлануы раслана. 18 яшькә җиткән барлык совет гражданнары төрле дәрәҗәдәге советларга депутатлар сайлауда катнашу хокукына ия була. ТАССР ЮСына — 21 яшькә җиткән, җирле советларга 18 яшькә җиткән барлык совет гражданнары сайлана ала. ТАССР Конституциясенең (1937) 10 нчы бүлегендә Татарстан АССРның гербы, флагы, башкаласы (Казан) билгеләнә, 11 нче бүлектә Конституциягә үзгәрешләр кертү тәртибе раслана (аңа үзгәрешләр кертү ТАССР ЮС депутатларының кимендә өчтән икесенең тавышы б-н ТАССР ЮС тарафыннан кабул ителгән карар буенча гына, аны РСФСР ЮС раславы б-н гамәлгә ашырыла).

ТАССРның чираттагы Конституциясе 1978 нең 31 маенда ТАССРның 9 нчы чакырылыш ЮСның 9 нчы сессиясендә СССР (1977) һәм РСФСР (1978) Конституцияләренә нигезләнеп кабул ителә. 1978 елгы ТАССР Конституциясе тексты 10 кисәктән, 16 бүлектән һәм 161 маддәдән тора. 1 нче кисәктә Татарстан АССРның эшче, крәстиян һәм интеллигенциянең, респ-каның күпмилләтле барлык хезмәт ияләренең ихтыярын һәм мәнфәгатен чагылдыручы соц. гомумхалык дәүләте булуы ассызыклана. Халык дәүләт хакимиятен ТАССРның сәяси нигезен тәшкил итүче халык депутатлары советлары аша гамәлгә ашыра дип билгеләнә. Совет дәүләтенең оештырылу һәм эшчәнлегенең төп принцибы булып демократик централизм (бер үзәктән идарә итү), ягъни түбәннән югарыга кадәр барлык дәүләт хакимияте органнарының сайланулы булуы, аларның халык алдында хисап тотуы, югарыдагы органнар карарларын үтәүнең түбәндәгеләре өчен мәҗбүри булуы тора. Дәүләт тормышындагы иң мөһим мәсьәләләр *референдумга* чыгарыла ала. ТАССР Конституциясенең (1978) 6 нчы маддәсендә Коммунистлар партиясе совет җәмгыятенең җитәкче һәм юнәлеш бирүче көче, аның сәяси системасы, дәүләт һәм иҗтимагый оешмалар үзәге дип күрсәтелә. Шуның б-н бергә иҗтимагый оешмаларга һәм хезмәт коллективларына дәүләт һәм җәмәгать эшләре б-н идарә итүдә катнашу хокукы бирелә. ТАССР икътисадының нигезен дәүләт милкен (бөтен халык байлыгы); колхоз-кооперация милкен; профсоюз һ.б. иҗтимагый оешмалар милкен үз эченә алган җитештерү чараларына соц. милек тәшкил итә. Җир, җир асты байлыклары, сулар, урманнар, төп җитештерү чаралары, сәнәгать, а.-х., төзелеш, сәүдә һәм социаль-көнкүреш пр-тиеләре, транспорт һәм элемтә чаралары, банклар, шәһәрләрдәге төп торак фонды фәкать дәүләт махсус милкенә карый. Колхозлар һ.б. кооперация оешмалары милкен устав буенча каралган бурычларны тормышка ашыру өчен кирәк булган җитештерү чаралары һәм башка төрле милек тәшкил итә. Колхозлар файдалана торган җир аларга элеккечә, бушлай һәм сроксыз файдалануга, ягъни мәңгегә беркетелә. Профсоюзлар һәм иҗтимагый оешмалар милкенә аларның бурычларын тормышка ашыру өчен кирәк булган милек керә. Гражданнарның шәхси милкендә — хезмәт керемнәре һәм җыелган акчалары, торак йорт һәм ярдәмче шәхси хуҗалык, шәхси куллану әйберләре һәм җайланмалар, көндәлек кирәк-яраклары булса, файдалануда — ярдәмче хуҗалык, бакчачылык һәм яшелчәчелек, индивидуаль торак төзелеше өчен бирелгән җир участогы була ала. ТАССР Конституциясе (1978) совет кешесенең ирекле хезмәтен халыкның тормышын яхшырту чыганагы буларак карый һәм иҗтимагый җитештерүнең иң югары максатын кешеләрнең матди һәм рухи ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерүдә күрә. Дәүләт илдә «һәркемнән — сәләтенчә, һәркемгә — хезмәтенчә» принцибы тормышка ашырылуын игълан итә. ТАССР икътисады РСФСР икътисадының состав өлешен тәшкил итә, ә аның б-н җитәкчелек итү дәүләтнең социаль-икътисади үсеш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Дәүләт җәмгыятьнең социаль яктан бертөрлелеген көчәйтүгә, СССРдагы барлык милләтләрне һәм халыкларны үзара якынайтуга һәм үстерүгә ярдәм итәргә тиеш була. 2 нче кисәктә совет гражданнары хокукларының киң спектры бирелә, уртак СССР гражданлыгы раслана. Чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, нинди расадан һәм милләттән булуына, җенесенә, белеменә, теленә, шөгыленең төренә һәм үзенчәлегенә, торган урынына карамастан, барлык гражданнар Конституция (1978) нигезендә дәүләт тарафыннан закон каршында яклануга тигез хокуклы. Гражданнарның хезмәткә, ял итүгә, ш.у. картлыкта, авырганда, хезмәткә сәләтен югалтканда, ш.у. туендыручысын югалтканда матди тәэмин ителүгә хокукларыннан тыш, һәр граждан сәламәтлеген саклауга; торакка; мәхкәмә яклавына; ш.у. түләүсез белем алырга; мәдәният казанышларыннан файдаланырга; дәүләт һәм җәмәгать эшләрен идарә итүдә катнашырга; вазифаи затлар, дәүләт һәм иҗтимагый органнар эшен тәнкыйтьләргә һәм шикаять бирергә хокуклы. Гражданнарга элеккечә сүз, матбугат, җыелышлар, митинглар, урамда оешып йөрү, демонстрацияләр, иҗат, җәмәгать оешмаларына берләшү, вөҗдан иреге, ш.у. шәхес, торак иминлеге, хат алышу, телефоннан сөйләшү, телеграф һәм хәбәрләшүдә сер саклау тәэмин ителә. Гражданнар Конституцияне һәм законнарны үтәргә; намус б-н хезмәт итәргә; соц. милекне сакларга һәм ныгытырга; дәүләт мәнфәгатьләрен якларга; ватанны сакларга; гражданнарның милли горурлыгын, башкаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен ихтирам итәргә; балалар тәрбияләүне кайгыртырга; табигатьне сакларга; соц. җәмгыять тормышы кагыйдәләрен хөрмәт итәргә; тарихи истәлекләрне һ.б. мәдәни кыйммәтләрне сакларга; халыклар арасындагы дуслык һәм хезмәттәшлекне үстерүгә булышырга бурычлы. ТАССР Конституциясенең (1978) 3 нче кисәгендә Татарстан АССРның РСФСР составындагы совет соц. дәүләте булуы ассызыклана һәм аның вәкаләтләре билгеләнә: респ-ка Конституциясен кабул итү, аңа үзгәрешләр кертү һәм аның үтәлешенә күзәтчелек итү; респ-ка законнарын кабул итү; районнарга бүленешне билгеләү; дәүләт тәртибен, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау; дәүләт хакимияте һәм идарәсенең респ-ка һәм җирле органнарын оештыру тәртибен һәм эшчәнлекләрен билгеләү; социаль-икътисади сәясәт үткәрү; респ-ка икътисады б-н җитәкчелек итү; дәүләт икътисад һәм социаль үсеш планнарын, дәүләт бюджетын эшләү һәм раслау, аларның үтәлеше турындагы хисапларны раслау; респ-кага буйсынудагы районнар һәм шәһәрләр бюджетының үтәлешенә җитәкчелек итү; җирле керемнәрне билгеләү; респ-ка карамагындагы халык хуҗалыгы тармаклары б-н җитәкчелек итү; җир, җир асты байлыклары, урманнар һәм сулардан файдалануны контрольдә тоту; әйләнә-тирә мохитне саклау; торак-коммуналь хуҗалык, сәүдә һәм җәмәгать туклануы, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү, торак төзелеше, шәһәрләрне һәм башка торак пунктларны төзекләндерү, халык мәгарифе, мәдәни һәм фәнни оешмалар һәм учреждениеләр, сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт, социаль тәэминат, тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне саклау һ.б. б-н җитәкчелек итү. СССР һәм РСФСР законнары ТАССР терр-ясендә мәҗбүри була. 4–8 бүлекләрдә ТАССР ЮСның; ТАССР МСның; ТАССР министрлыклары һәм дәүләт ком-тларының; Халык депутатларының район, шәһәр, шә-

һәрләрдәге районнар, посёлок һәм авыл советлары һәм аларның башкарма ком-тларының; суд, арбитраж һәм прокуратура органнарының оештырылу һәм эшчәнлек принциплары билгеләнә, аларның вәкаләтләре раслана. ТАССР ЮСның вәкаләт чоры — 5 ел, җирле советларныкы 2,5 ел дип күрсәтелә. Бөтен советларга да депутатлар сайлау элеккечә гомуми, тигез һәм туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү тәртибендә 18 яше тулган барлык гражданнар өчен үткәрелә. ТАССРның дәүләт планы һәм дәүләт бюджеты РСФСРның дәүләт планы һәм дәүләт бюджетының состав өлешен тәшкил итә. 9 нчы бүлектә дәүләт символлары (ТАССР Дәүләт гербына берникадәр үзгәрешләр кертелә) һәм респ-ка башкаласы; 10 нчы бүлектә — респ-ка Конституциясен мөстәкыйль рәвештә үзгәртү тәртибе раслана.

Татарстан дәүләтчелеге үсешендә 1990 елда «*Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт суверенитеты турында декларация*»*се* кабул ителү әһәмиятле тарихи вакыйга булып тора. Респ-каның дәүләт һәм җәмгыять строе нигездән үзгәрешләр кичерү нәтиҗәсендә (к. *Автономия*) 1992 нең 6 ноябрендә ТРның 12 нче чакырылыш ЮСның 12 нче сессиясендә ТРның яңа Конституциясе кабул ителә, 2002 нең 19 апрель Законы нигезендә аңа җитди үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелә. ТР Конституциясе 7 кисәктән, 4 бүлектән һәм 124 маддәдән тора.

1 нче кисәк Татарстан Респ-касы Россия Федерациясе б-н РФ Конституциясе, ТР К. һәм «*Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында*» *Шартнамә* нигезендә берләшкән һәм РФ субъекты булган демократик хокукый дәүләт дип раслап, респ-ка Конституциясенең нигезен ныгыта. Татарстанның статусы һәм терр. чикләре РФ ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый. ТР үз вәкаләтләре чикләрендә мөстәкыйль рәвештә халыкара һәм тышкы икътисади мөнәсәбәтләрдә катнаша. ТР К. буенча, кеше, аның хокуклары һәм иреге иң югары кыйммәт булып исәпләнә. Респ-када хакимиятнең бердәнбер чыганагы булып аның күпмилләтле халкы санала, халык үз хакимиятен турыдан-туры дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары аркылы гамәлгә ашыра. Халык хакимиятенең иң югары чагылышы референдум һәм иркен сайлаулардан гыйбарәт. ТР үз карамагы чикләрендә респ-ка Конституциясен кабул итә һәм аңа төзәтмәләр кертә, ш.у. респ-ка законнарын һ.б. норматив актларны кабул итә; чит илләр, аларның субъектлары һәм адм.-терр. оешмалар б-н халыкара һәм тышкы икътисади мөнәсәбәтләр урнаштыра; халыкара килешүләр төзи, вәкилләр алмаша, халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнаша; РФ субъектлары б-н мөнәсәбәтләр урнаштыра; социаль-икътисади программалар ярдәмендә икътисад үсешен көйли; үзенең дәүләт бүләкләрен булдыра һ.б. Татар һәм рус телләре респ-ка терр-ясендә дәүләт телләре булып таныла. ТР К. дәүләт хакимиятенең закон чыгару, башкару һәм суд хакимиятләренә бүленүен раслый; җирле үзидарәне гарантияли. Анда идеологик күптөрлелек һәм иҗтимагый оешмаларның дәүләт эшләре б-н идарә итүдә катнашу хокукы раслана. Бу кисәктә ТРның дөньяви һәм социаль дәүләт булуы, көч куллануны һәм сугышны кире кагуы, татар халкының милли мәдәниятен, телен һәм үзенчәлекләрен үстерүгә ярдәм итүе ассызыклана. Татарстанда җир, җир асты, су, урман һ.б. табигый байлыклар һәм үсемлекләр дөньясы халык тормышы һәм эшчәнлегенең нигезе дип белдерелә. Респ-ка икътисадының нигезен социаль базар хуҗалыгы тәшкил итә, анда хуҗалык эшчәнлеге иреге һәм милекнең (хосусый, дәүләт, муниципаль һ.б.) күп төрлелеге, аларны хокукый яклау өчен тигез шартлар тәэмин ителә. Икътисади мөнәсәбәтләр гражданнар б-н дәүләт, куллануычы б-н җитештерүче, эш башкаручы б-н эш бирүче арасындагы тиңлек нигезендә төзелә. ТР К. җир һ.б. табигый ресурсларның хосусый, дәүләт, муниципаль милек була алуын ассызыклый, милек кагылгысызлыгын раслый. Респ-када икътисади эшчәнлекне монополияләштерү рөхсәт ителми, ә дәүләт урта һәм кече бизнесны үстерүгә ярдәм итә. ТР гражданы бер үк вакытта РФ гражданлыгына да ия. 2 нче кисәктә барлык гражданнарның закон һәм суд каршында тигез хокуклы булуы әйтелә. Чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, нинди расадан һәм милләттән булуына, җенесенә, белеменә, теленә, сәяси карашына, дини мәсләгенә, шөгыленең төренә һәм үзенчәлегенә, торган урынына карамастан, алар дәүләт тарафыннан яклануга тигез хокуклы. ТР К. буенча, гражданнарның шәхси хокуклары: тормышы, абруе, шәхси иреге яклану һәм шәхес кагылгысызлыгы; үз милләтен билгеләү һәм күрсәтү; туган телендә аралашу; аралашу, тәрбия, белем алу һәм иҗат итү өчен тел сайлау иреге; юридик ярдәм алу. Гражданнарга шәхси тормыш, шәхси һәм гаилә сере, торак кагылгысызлыгы, шәхеснең намусын һәм абруен яклау, хат алышу, телефоннан сөйләшү, почта, телеграф һәм хәбәрләшүдә сер саклау тәэмин ителә. ТР К. һәркемгә сүз, матбугат, иҗат, фикер һәм инану иреге, җыелышлар, митинглар һәм демонстрацияләр, профсоюз һ.б. иҗтимагый оешмаларга берләшү, дәүләт һәм җәмгыять эшләре б-н идарә итүдә катнашу, ш.у. — вөҗдан иреге һәм дин тоту, күчеп йөрү, яшәү һәм тору урынын сайлау һ.б. ирекләре гарантияли. Моннан тыш, гражданнар дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарәгә сайларга һәм сайланырга хокуклы (к. *Сайлау системасы*), аларга шәхсән мөрәҗәгать итә һәм индивидуаль һәм коллектив мөрәҗәгатьләр җибәрә алалар; суд яклавына, дәүләт һәм муниципаль хезмәткә тигез хокуклы. Гражданнарның социаль-икътисади һәм мәдәни хокуклары: хосусый милеккә, хезмәткә, эш ташлауга, хезмәт урынындагы бәхәсләргә, торакка, белем алуга, куллanучылар хокукы яклануга, сәламәтлек саклауга, әйләнә-тирә мохит саклануга, мәдәни тормышта катнашуга, картлыкта, авырганда, хезмәткә сәләтен тулысынча яки өлешчә югалтканда, туендыручысын югалтканда, бала тәрбияләгәндә һ.б. матди тәэминителүгә хокук. ТР К. гражданнарның бурычларын да билгели: алар Конституция һәм законнарны үтәргә, салымнар түләп, дәүләт чыгымнарында катнашырга, табигатькә һәм әйләнә-тирә мохиткә сакчыл мөнәсәбәт күрсәтергә, хәрби хезмәт үтәргә, башка кешеләрнең хокукын һәм иреген бозмаска, дәүләт һәм җәмгыять куркынычсызлыгына, җәмгыятьтәге тәртипкә, халыкның сәламәтлегенә һәм әхлагына зыян китермәскә; дәүләт символларын хөрмәт итәргә; мәдәни кыйммәтләрне, тарихи истәлекләрне сакларга бурычлы. 3 нче кисәктә респ-каның адм.-терр. төзелеше, 4 — 5 нче кисәкләрдә — дәүләт башлыгы — *Татарстан Республикасы Президентының вәкаләтләре*, парламент — *Татарстан Республикасы Дәүләт Советының* (1995 кә кадәр *Татарстан Республикасы Югары Советы*), хөкүмәт — *Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының*, *Татарстан Республикасы дәүләт комитетларының*, *Татарстан Республикасы министрлыкларының*, ТР мәхкәмә хакимияте һәм прокуратурасының, җирле үзидарәләрнең оештырылу һәм эшчәнлек принциплары һәм компетенцияләре билгеләнә. 6 нчы кисәк ТР дәүләт символлары һәм башкаласына багышлана. 7 нче кисәктә респ-ка Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе билгеләнә; 1 нче маддә нигезләмәләре ТР референдумы нәтиҗәләре буенча, ә башка маддәләр Дәүләт Советы (1995 кә кадәр ЮС) депутатларының кимендә өчтән икесенең тавышы б-н карар кабул ителгәч үзгәртелә ала. Төзәтмәләр ТР Президенты тарафыннан кире кагылган очракта, ТР Президенты һәм ТР Дәүләт Советы тарафыннан тигезлекле нигездә килештерү комиссиясе төзелә; ТР Конституциясенең элек респ-ка парламентының квалификацияле күпчелеге тарафыннан кабул ителгән редакциясендәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр турындагы законның икенче тапкыр хуплануы аның ТР Президенты тарафыннан имзалануына китерә. Кабул ителгән үзгәрешләргә нигезләнеп, хәзер үз көчендә булган ТР К. законнар эшләү өчен җирлек булып хезмәт итә һәм демократияне ныгыту, Татарстанның социаль-икътисади үсеше, федерализм принципларында РФ халыклары бердәмлеген саклау өчен шартлар тудыра .

Чыг.: Татарстан Республикасы Конституциясе. К.,1993; Конституция Татарской Социалистической Советской Республики: Проект. К., 1926; Конституция (Основной Закон) Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. К., 1937; Конституция (Основной Закон) Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. К., 1978; Конституция Республики Татарстан. К., 1992; Закон Республики Татарстан «О внесении изменений и дополнений в Конституцию Республики Татарстан» от 19 апреля 2002 г. // Республика Татарстан. 2002. 30 апр.; Конституция Республики Татарстан .К., 2014.

*Әд.:* Хафизов Ш.Ш. Развитие советской государственности татарского народа. К., 1966; История национальной государственности в Татарии. К., 1982; Железнов Б.Л. АССР — высшая форма советской автономии. К., 1984; шул ук. Правовой статус Республики Татарстан. К., 1996.

*Б.Л.Железнов, Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ КУЛЛАНУЧЫЛА́Р ҖӘМГЫЯТЬЛӘРЕ́ БЕРЛЕГЕ́**, к. *Сатып алучы-кулланучылар кооперациясе.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ МАТБУГА́Т, ТЕЛЕРАДИОТАПШЫРУЛА́Р ҺӘМ МА́ССАКҮЛӘМ КОММУНИКА́ЦИЯЛӘР МИНИ́СТРЛЫГЫ**, тарихы Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна советының 1917 ел 16 ноябрь карары б-н Губерна советы каршында (1919 дан — Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары Казан губерна советы башкарма ком-ты каршында) матбугат бүлеге оештырылудан башлана. Бүлек БҮБК һәм РСФСР ХКСның 1920 ел 27 май Декреты нигезендә Дәүләт нәшриятының Казан бүлеге итеп үзгәртелә, ТАССР ХКСның 1941 ел 11 апрель карары (карар шул елның октябренә кадәр гамәлдә була), 1945 ел 30 июль карары һәм ТАССР ХКСның 1946 ел 11 гыйнвар күрсәтмәсе б-н ТАССР ХКС (МС) каршындагы Нәшриятлар һәм полиграфия идарәсе буларак торгызыла, ТАССР МСның 1949 ел 5 сентябрь карары б-н — ТАССР МС каршындагы Полиграфия сәнәгате, нәшриятлар эшләре һәм китап сәүдәсе идарәсе, ТАССР ЮС Президиумының 1953 ел 30 апрель карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1953 ел 30 май Указы б-н — ТАССР Мәдәният министрлыгының нәшриятлар һәм полиграфия сәнәгате бүлеге, КПССның Татарстан өлкә ком-ты Бюросы һәм ТАССР МСның 1963 ел 30 октябрь карары б-н — ТАССР МС каршындагы Матбугат идарәсе, ТАССР ЮС Президиумының 1972 ел 19 сентябрь Указы б-н — ТАССР МС каршындагы Нәшрият эшләре, полиграфия һәм китап сәүдәсе идарәсе, ТАССР ЮС Президиумының 1979 ел 22 август Указы б-н — ТАССР Нәшрият эшләре, полиграфия һәм китап сәүдәсе дәүләт ком-ты, ТССР ЮСның 1991 ел 5 июль карары б-н — ТССР (1992 дән — ТР) Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы, ТР Дәүләт Советының 1999 ел 15 сентябрь карары б-н әлеге исемдәге Министрлык итеп үзгәртелә. Гражданнарның һәм халыкларның сүз, матбугат, иҗат иреге, мәгълүмат алуга һәм мәдәният казанышларыннан файдалануга хокуклары өлкәсендә дәүләт сәясәтен уздыруны гамәлгә ашыра. Канцелярияне, бухгалтерияне, җитештерү-техник, планлаштыру-икътисад (1993 тән — икътисад һәм финанс), кадрлар бүлекләрен үз эченә ала. Министрлык карамагына Татарстан китап нәшрияты, Татарстан китап берләшмәсе, К.Якуб исем. полиграфия комб-ты, Дәүләт китап палатасы, «Мәгариф» нәшрияты (1993 тән), 39 район типографиясе, 15 респ-ка һәм 49 район газета-журнал редакцияләре керә. ТР Президентына, ТР МКна (1991 гә кадәр — ТАССР МСна һәм РСФСРның шундый ук Дәүләт ком-тына) буйсына. ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май карары б-н гамәлдән чыгарыла, вазифаларының бер өлеше ТР Элемтә министрлыгына тапшырыла.

Дәүләт ком-ты рәисләре һәм министрлар: Н.С.Пушкарёв (1979–80), Е.А.Лисин (1980–85), Ә.С.Миндубаев (1985–89), Ш.Ш.Хамматов (1989–92), И.Г.Әхмәтҗанов (1992–99), З.Р.Вәлиева (1999–2001).

Ш.у.к. *Китап белеме.*

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ́ ҮСТЕРҮ́ ИНСТИТУТЫ́**, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагында, 1928 елда РСФСР Мәгариф халык комис-ты каршында Укытучыларның белемен күтәрү үзәк ин-ты бүлеге буларак ачыла. 1931 дән Татарстан халык мәгарифе хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү ин-ты, 1939 дан Татарстан укытучыларының белемен күтәрү ин-ты, 1992 дән Татарстан педагогларының квалификациясен күтәрү ин-ты, 1993 тән Татарстан Респ-касы мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү ин-ты, 2005 тән хәзерге исемдә. Пед. хезмәткәрләргә, мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә барлык белгечлекләр буенча өзлексез һөнәри белем бирүне; югары белем базасында дефектологларны, татар теле һәм әдәбияты укытучыларын, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының башлангыч белем бирү, төп һәм урта белем бирү пед. хезмәткәрләрен, пед. кадрларны аттестацияләү буенча экспертларны яңадан әзерләүне оештыра. Институт ТРның әйдәп баручы фәнни-методик үзәге булып санала; фәнни-тикшеренү эшенең төп юнәлеше — гомуми урта белем бирү проблемалары, милли мәгарифне фәнни-методик рәвештә алып бару, урта һөнәри белем бирүне яңарту, инновацион пед. тәҗрибәне гомумиләштерү һәм тарату. Институт тарафыннан дәреслекләр, методик ярдәмлекләр һәм тәкъдимнәр чыгарыла.

Институт составында 3 үзәк (һөнәри белем бирүне үстерү, һөнәри осталыкны үстерү, электрон укыту үзәкләре), 5 кафедра, 10 укыту-методика лаб-ясе эшли. Ел саен 9 меңнән артык кеше квалификациясен күтәрә. 2016 елга пед. коллективта 89 кеше, ш.и. 5 фән. д-ры, 38 фән. канд-ты эшли.

Институтның 3 уку-укыту бинасы бар, төп бинасы — элеккеге Киселёв йорты (Зур Кызыл ур.) — архит-ра һәм тарих истәлеге. Институт директорлары: Г.С.Закиров, И.И.Малкин, Ю.А.Туишев, М.У.Яхъяев, Р.Ә.Исламшин, И.Г.Һадиуллин, Р.Ф.Шәйхелисламов, Е.Г.Скобельцына, Ф.Х.Тарасова, Р.Г.Хәмитов, Р.Р.Бәдриева (2016 дан).

*Әд.:* Институт повышения квалификации и переподготовки работников образования Республики Татарстан (к 70-летию со дня основания). К., 1998; От науки к практике. Проблемы и достижения: Библиогр. указ. изданий ИПКРО РТ: В 3 вып. К., 1998–2000.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ МӘГЪЛҮМА́Т ҺӘМ МАТБУГА́Т МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасы Матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ́ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**, тарихы СССР Почталар һәм телеграфлар халык комис-ты каршындагы (1932 елдан — СССР Элемтә халык комис-ты, 1946–56 да, 1963 тән — СССР Элемтә министрлыгы, 1956–63 тә — РСФСР Элемтә министрлыгы) каршында Татарстан Элемтә респ-ка идарәсе оештырылудан (СССР Почталар һәм телеграфлар халык комис-тының 1930 ел 17 окт. циркуляры нигезендә) башлана. Идарә СССР элемтә министрлыгының 1967 ел 24 июнь боерыгы б-н — ТАССР Элемтә җитештерү-техник идарәсе, СССР элемтә, мәгълүматлаштыру һәм космос министрлыгының 1991 ел 15 гыйнвар боерыгы б-н — ТССР «Связьинформ» элемтә һәм мәгълүматлаштыру дәүләт пр-тиесе, ТР ЮСның 1993 ел 4 март карары б-н — ТР Элемтә министрлыгы, ТР Президентының 2005 ел 14 март Указы һәм ТР Дәүләт Советының 2005 ел 14 март карары б-н — ТР М.һ.э.м. итеп үзгәртелә. Элек элемтәнең барлык төрләренә (халыкара, шәһәрара, шәһәрләрдә һәм авылларда телефон элемтәсе, телеграф, почта элемтәсе, радио- һәм үткәргечле элемтә, радиотапшырулар, телевидение, махсус һәм фельдъегерлык элемтәсе) дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра; 2001–05 тә бу вазифаларга телекоммуникацияләр һәм мәгълүмат тапшыру челтәрен үстерү, массакүләм мәгълүмат чаралары, теле- һәм радиотапшырулар, матбугат, нәшрият һәм полиграфия эшчәнлеге, мәгълүмат алмашу һәм элемтә өлкәсендә лицензияләү тармакларында мәгълүматлаштыру мәсьәләләре өстәлә; хәзерге вакытта мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә дәүләт сәясәтен уздыра. Мәгълүмат-аналитика, мәгълүмати куркынычсызлык, мәгълүмати хезмәтләр һәм технологияләр үсеше, икътисади сәясәт, кадрлар һәм хезмәтне саклау, инвестицион сәясәт, телекоммуникация челтәрләре үсеше, элемтә хезмәтләре үсеше, теле- һәм радиотапшырулар хезмәтләре үсеше, бухгалтерия исәп-хисабы, хокукый тәэминат бүлекләрен, адм.-хуҗалык, автоматлаштыру һәм эш кәгазьләрен алып бару, гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм махсус эшләр, режимлы эш, махсус элемтә һәм мәгълүмат саклау секторларын, элемтә б-н оператив идарә, мәгълүмат технологияләре үзәкләрен үз эченә ала. 1990 елларда министрлык системасына 65 тән артык оешма һәм пр-тие, 21 йөз башында ТР Мәгълүмат технологияләре үзәге һәм «52 нче комплекс» керә. ТР Президентына һәм ТР МКна буйсына.

Министрлар: Р.Г.Җәләлов (1993–2005), Ф.М.Фазылҗанов (2005–10), Н.А.Никифоров (2010–12), Р.А.Шәйхетдинов (2012 дән).

Ш.у.к. *Элемтә.*

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ МӘДӘНИЯ́Т МИНИ́СТРЛЫГЫ**, Сәнгать эшләре, мәдәни-агарту оешмалары, кинофикация, полиграфия сәнәгате, нәшрият һәм китап сәүдәсе эшләре идарәләре, ш.у. ТАССР МС каршындагы Радиофикация ком-ты берләшү нәтиҗәсендә ТАССР ЮС Президиумының 1953 ел 30 апрель карары, РСФСР ЮС Президиумының 1953 ел 30 май Указы һәм ТАССР МСның 1953 ел 7 август карары нигезендә оештырыла. Соңыннан Кинофикация, Полиграфия сәнәгате, нәшриятлар эшләре һәм китап сәүдәсе идарәләре, Радиотапшырулар һәм телевидение ком-ты ТАССР Мәдәният министрлыгы составыннан аерылып чыга һәм турыдан-туры ТАССР МСна буйсындырыла (Ш.у.к. *«Татарстан» дәүләт*

*телерадиотапшырулар компаниясе, Татарстан АССР кинофикация дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы Матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы*). Дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыра, мәдәният (ш.и. сәнгать, кинематография, тарихи-мәдәни мирасны саклау һәм аннан файдалану), ял итүне оештыру һәм җәмгать оешмалары өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне көйли. Башта составында канцелярия; баш бухгалтерия; кинофикация, нәшрият һәм полиграфия сәнәгате, сәнгать, радиотапшырулар, мәдәни-агарту эшләре, капиталь төзелеш, планлаштыру-финанс, тәэминат бүлекләре; кадрлар секторы; хуҗалык бүлеге була. Хәзерге вакытта ТР М.м. составына тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне саклау һәм алардан файдалану буенча дәүләт контроле, кинематография баш идарәләре; шәһәрләрдә һәм районнарда мәдәниятне үстерү, милләтара мәдәни багланышлар үсеше һәм милли-мәдәни автономияләр һәм җәмгыятьләр б-н мөнәсәбәтләрне җайга салу; сәнгатьләр үсеше, иҗат берлекләре б-н үзара багланышлар; кинематография; дәүләт заказын һәм төзелеш эшләрен җайга салу; социаль-икътисади программалаштыру; хокук; бухгалтерия; мәгълүмат-аналитика; кадрлар бүлекләре; күчмә мәдәни һәм тарихи мирас секторы; ревизия төркеме; канцелярия керә. ТР М.м. карамагындагы оешмалар арасында терр. мәдәният органнары, театр, кинотеатр, концерт учреждениеләре, цирк, китапханәләр, кино күрсәтү җайланмалары, музейлар, клублар, уку йортлары, парклар, зooботаника бакчалары һ.б. бар. ТР Президентына, ТР МКна (1991 гә кадәр — ТАССР МС һәм РСФСРның Мәдәният министрлыгына) буйсына.

Министрлар: Ю.З.Закиров (1953–56), Х.Б.Рәхмәтуллин (1956–62), Б.М.Гыйззәтуллин (1962–73), Ә.С.Миндубаев (1973–76), И.Н.Алиев (1976–85), М.М.Таишев (1985–99), И.Г.Тарханов (1999–2005), З.Р.Вәлиева (2005–2011), А.М.Сибагатуллин (2011 дән). *Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ МИЛЛИ́ АРХИВЫ́** (ТР МА). 1919 елның 6 февралендә Казан губерна архивы (Казгубархив) буларак оештырыла. 1921 дән Татарстан Үзәк архивы, 1941 дән ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 1996 дан хәзерге исемдә. Казан губерна архивы РСФСР ХКСның «РСФСРда архив эшен үзгәртү һәм үзәкләштерү турында»гы 1918 ел 1 июнь Декретына нигезләнеп оештырыла, РСФСР архив эшенең Төп идарәсе вәкиле итеп Казан губернасы буенча проф. И.А.*Стратонов* билгеләнә. 4 бүлектән тора: галимнәр, уку йортлары, чиркәүләр; мәхкәмә оешмалары; хәрби оешмалар; Казан округының аралашу юллары архивлары. 1921 нең гыйнварыннан, ТАССР төзелү б-н, Казан губерна архивы Татарстан Үзәк архивы итеп үзгәртелә, ул ТАССР Мәгариф Халык комис-тына буйсына. РСФСР архив эше Баш идарәсе вәкиле итеп Е.И.Чернышёв билгеләнә. 1922 нең маенда Татүзәкархив ТАССР ХКС карамагына күчә. Бердәм дәүләт архив фондының (БДАФ) секцияләр бүленешенә нигезләнеп, ТАССР архив фонды сәяси, икътисади, юридик, тарихи-мәдәни, хәрби һәм көнчыгыш секцияләргә бүленә. 1925 нең февралендә РСФСР Үзәк архивы коллегиясе раслаган «Бердәм дәүләт архив фонды турындагы күрсәтмәләр» буенча, БДАФ документлары революциягә кадәрге (тарихи архив) һәм совет (Окт. рев-циясе архивы) чорларына бүленә. Регионнарда бу карар 1927 дән, Бөтенроссия ҮБКның урыннарда Окт. рев-циясе архивларын булдыру турындагы декреты чыкканнан соң тормышка ашырыла башлый. Татүзәкархив документларында беренче бүленеш 1927 нең 1 октябреннән 1928 нең 1 октябренә кадәрге чорны үз эченә алган хисапта күренә. ТАССРда әлеге архивлар тулысынча 1935 тә генә мөстәкыйль бәрәмлекләргә аерылалар. 1939 да ТАССР Эчке эшләр халык комис-ты приказлары нигезендә ТАССР Үзәк архив идарәсе үзенә буйсындырылган архивлары б-н ТАССР НКВДсы Архив бүлеге карамагына кабул ителә. 1941 дә Тарихи архив б-н Окт. рев-циясе архивы ТАССР Үзәк дәүләт архивына берләшә, анда рев-циягә кадәрге фондлар, Окт. рев-циясе һәм соц. төзелеш фондлары, яшерен фондлар, фәнни-белешмә әдәбият бүлекләре була. 1962 нең гыйнварында Архив бүлеге һәм ТАССР Үзәк дәүләт архивы ТАССР МС карамагына күчә. 1964 нең мартында ТАССР Үзәк дәүләт архивының структурасы яңадан карала: ведомство архивлары, экспертиза һәм туплау; документаль материалларны файдалану һәм бастырып чыгару; саклау, теркәү һәм фәнни-белешмә аппарат; кинофотофон бүлеге; документларны реставрацияләү һәм микрофильмнар ясау лабораториясе бүлекләре оештырыла. 1992 нең февралендә ТАССР Үзәк дәүләт архивы Татарстан Республикасы Үзәк дәүләт архивы итеп үзгәртелә (ТР ҮДА). ТР МК каршындагы *Баш архив идарәсенә* буйсына.

ТР Милли архивында 8 меңнән артык фонд, 1709–2005 елларга караган 2 млн. чамасы саклау берәмлеге бар (аерым документлар 11–17 йөзләргә карый). Архив документларында сәнәгать үсеше тарихы буенча вак һөнәрчелек тибындагы кече пр-тиеләрдән алып (киез итек басу, туку, агач эшкәртү һ.б.), эре сәнәгать пр-тиеләренә кадәр (бертуган Крестовниковларның шәм-стеарин, сабын кайнату, глицерин җитештерү һәм Алафузовлар күн з-ды һ.б.) мәгълүмат тупланган; нефть чыганакларын эшкәртү; Рус-Азия, Идел-Кама, Дворяннар җир банкы, Крәстияннәр җир банкы һ.б. банк бүлекләре һәм ф-лары барлыкка килү; җир биләү һәм җирдән файдалану мөнәсәбәтләре; коры җир һәм су транспорты коммуникацияләрен төзү тарихы турында мәгълүматлар бар. Документларның шактый өлеше төбәкнең фән, мәдәният һәм мәгариф үсеше тарихын, ш.и. Казан ун-тында галимнәр Н.И.Лобачевский, А.М.Бутлеров, Н.Н.Зинин, И.М.Симонов, П.Ф.Лесгафт, Н.А.Миславский, В.М.Бехтерев, И.А.Бодуэн де Куртенэ, В.И.Григорович һ.б. җитәкчелегендә күп кенә фәнни мәктәпләр һәм юнәлешләрнең оешуы һәм эшчәнлеге (к. *Казан фәнни мәктәпләре*); *Шәрекъ бүлеге, Казан татар укытучылар мәктәбе* эшчәнлеге, Казан ун-тында һәм Казан руханилар академиясендә күренекле галимнәр И.И.Хәлфин, М.К.Казимбәк, О.М.Ковалевский, Н.Я.Бичурин, Н.Ф.Катанов, Е.А.Малов һ.б. эшчәнлеге тарихын чагылдырган; ун-тта һәм Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә рус әдәбияты классиклары Г.Р.Державин, Л.Н.Толстой, С.Т.Аксаков, П.И.Мельников-Печерский, рәссамнар И.И.Шишкин, В.И.Якобиның укыган еллары; татар милли мәдәнияте, фәне һәм мәгарифе үсеше, ш.и. татар мәктәпләре, мәдрәсәләре ачылу һәм эшләү; Казанда татар телендә беренче газета һәм журналлар бастырып чыгару, татар театры барлыкка килү, татар әдәбияты классиклары Г.Тукай, Г.Исхакый, Г.Камал, мәгърифәтчеләр К.Насыйри, Ш.Мәрҗәни тормышы һәм эшчәнлеге турында; Казан руханилар академиясе фондында, профессорлар П.В.Знаменский, М.А.Машанов, Н.И.Ильминский, М.К.Казимбәк, Н.Ф.Катановларның шәхси фондларында 11, 15–19 йөзләргә караган рус, француз, немец, грек, латин, гарәп, фарсы, төрек, монгол, тибет һ.б. телләрдәге кульъязмалар тупланган. 8 йөздә Басрада (хәзер Иран терр-ясендә) яшәгән галим-лингвист Сибәвәйхинең танылган «Китабы» күчермәсе — пергаментка язылган 11 йөз гарәп кульъязмасы – иң борынгы документ булып тора. Социаль катлау учреждениеләре документлары, мөселман һәм христиан метрика кенәгәләре, тәүбә язмалары һәм ревизия тасвирламаларында генеалогик мәгълүматлар бар. Адм.-полиция һәм мәхкәмә органнары фондларында төрле сәяси түгәрәкләр һәм партияләр барлыкка килү, агентура мәгълүматлары, «Мәгариф лигасы» («Лига образования») һәм «Иттифакъ» (1911) мөселман җәмгыятьләре, Бөтенроссия мөселман союзы (Устав, 1911), «Мөселманнар берлеге» (Программа, 1911), Дәүләт Думасының мөселман фракциясе һәм аның лидеры С.Н.Максуди, Россия мөселманнары съездлары (стенограммалар, 1904–14) турында мәгълүматлар саклана. 1917 дән соңгы чорга караган документлар Россия империясенең дәүләт аппараты бетерелгәннән соң төбәктә идарә оештыру һәм хуҗалык-икътисад төзелеше буенча беренче чаралар турында, ТАССР төзелү, ТАССРның Бөтенроссия ҮБК Президиумы каршындагы вәкиллегенең эшчәнлеге турында, сәнәгатьне национализацияләү, сәнәгатьнең нефть, нефть химиясе, газ, химия, машина төзү һ.б. тармаклар үсеше, эре сәнәгать пр-тиеләре төзелеше һәм эшчәнлеге, җирне социальләштерү процесслары, а.х. үсеше турында сөйли. Халык мәгарифе, мәдәнияте, иҗади берләшмәләр документлары респ-кадагы мәдәни үсеш процессларын: мәктәп һәм мәдрәсәләрне, земство карамагындагы һәм чиркәү-мәхәллә мәктәпләрен, гимназияләрне, реаль уч-щеләрне 1 нче, 2 нче дәрәҗә бердәм хезмәт мәктәпләренә үзгәртеп коруны; респ-када татар телен гамәлгә кертү, татар телен гарәп язуыннан латин язуына (1927), соңрак *кириллицага* күчерүне; Казан югары уку йортларының уку-укыту һәм фәнни эш-

чәнлеген; респ-када фән үсеше, СССР ФАнең Казан ф-лы ачылуны; фәнни-тикшеренү оешмалары эшчәнлеген; Татар акад. театрының, Татар опера һәм балет театрының эшен, татар халык һәм симф. музыкасы, әдәбият, сынлы сәнгать үсешен чагылдыра. Архив документларында респ-ка җитәкчеләре, фәнни һәм иҗади интеллигенция, крәстияннәр, руханиларга карата 1930 еллардагы сәяси репрессияләр, ш.у. мәчетләр һәм чиркәүләр ябылу турында мәгълүматлар бар. Архивта күп кенә фән, мәдәният һәм сәнгать әһелләренең шәхси фондлары саклана. Анда респ-каның фәнни-тикшеренү, проектлау, сәнәгый һәм төзелеш оешмаларының фәнни-техник документлары тупланган, алар сәнәгатьтәге, төзелештәге, фәнни, проектлау һәм технол. тикшеренү, мөһим объектлар төзелеше, мәдәни һәйкәлләрне торгызу, ш.у. бакчачылык, урман орлыкчылыгы һ.б. өлкәләрдәге эш нәтиҗәләрен чагылдыралар. Фотодокументлар арасында — мөселман һәм христиан дине вәкилләре, Казан ун-ты һәм Казан вет. ин-ты студентлары, төрле сәяси партияләр әгъзалары портретлары, 19–20 йөз башы Казан күренеше б-н открыткалар һәм фотографияләр. Респ-кадагы иҗтимагый-сәяси вакыйгалар, фән һәм техника үсеше, халык хуҗалыгы, мәдәният, сәнгать һәм спорт тармаклары тарихын чагылдыручы рев-циядән соңгы чор фотодокументлары саклана. ТР МАнда ш.у. 7,6 меңгә якын үзәк һәм җирле газеталар тупланмасы, 26 мең китап һәм журнал бар. ТР МА Татарстан Респ-касы Архив фонды документларына дәүләт теркәве алып бара һәм саклый, аларны реставрацияли, бозылудан саклый, саклау өчен күчермәсен ала; даими саклана торган документларны сайлап алуны һәм кабул итүне оештыра; ретроспектив документ мәгълүматына җәмгыять ихтыяҗын өйрәнә; дәүләт яки башка учреждениеләрнең, ТР һәм РФ гражданнарының, чит ил оешмалары һәм гражданнарының архив документлары буенча сорауларын үти, аларга тематик һәм социаль-хокукый характердагы белешмәләр, уку залында файдалану өчен документлар бирә; документлар күргәзмәсе оештыра, массакүләм мәгълүмат чаралары аша архив документлары б-н таныштыра; документлар җыентыгы, белешмә-мәгълүмати һәм фәнни-популяр әдәбиятны басмага әзерли; архив фондларыннан мәгълүмат эзләүне тәэмин итү өчен традицион һәм автоматлаштырылган архив белешмәләре системасын төзи.

Архив тарафыннан 30 га якын документлар җыентыклары һәм белешмәлекләр нәшер ителә. Беренче фәнни-популяр җыентык — «Бөтендөнья сугышы һәм Февраль революциясе чорында патша армиясе» («Царская армия в период мировой войны и Февральской революции») 1932 дә басыла. Бөтенсоюз серияләре кысасында басылган җыентыклар: «Татарстан АССРда индустрияләштерү. 1926–1941 еллар» («Индустриализация в Татарской АССР. 1926–1941 гг.» (1968), «Татарстан АССРда авыл хуҗалыгын күмәкләштерү» («Коллективизация сельского хозяйства Татарской АССР (1927–1937)» (1968), «Татарстанда культура төзелеше. 1917–1941» («Культурное строительство в Татарии. 1917–1941» (1971; 1976 да 1941–70 еллар материалы чыга), «Татарстанда нефть, газ һәм нефть химиясе» («Нефть, газ и нефтехимия Татарии») (1–2 т., 1978–79; 1976–80 елларда РСФСР архив учреждениеләренең фәнни-мәгълүмати эшчәнлеге өлкәсендә яхшы фәнни хезмәт буларак 2 нче бүләккә лаек була), «1917–1980 елларда Татарстанда матбугат, радиотапшырулар һәм телевидение» («Печать, радиовещание и телевидение Татарии 1917–1980 гг.») (1981; диплом һәм СССР ВДНХсының көмеш медале), «Варислар хәтеренә лаек. 1767–1917 елларда Казан шәһәре башлыклары» («Достойны памяти потомков. Городские головы Казани 1767–1917 гг.» 2002; 2001–02 елларда архив белеме, документ белеме һәм археография өлкәсендә Бөтенроссия фәнни эшләр конкурсы дипломы). «Шәфкатьлелекнең тамырлары тирән» («У милосердия древние корни», 1–2 китап, 2002–03), «Татарстан — 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышының җиңү арсеналларыннан берсе» («Татарстан — один из арсеналов победы в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг.», 2004), «1876–1917 елларда Казан татар укытучылар мәктәбе» («Казанская татарская учительская школа 1876–1917 гг.», 2005) һ.б. серияләрдән документлар җыентыклары фәнни җәмәгатьчелекнең югары бәясенә лаек була.

Архив җитәкчеләре: Окт. рев-циясе архивы — А.А.Тарасов (1928–29), В.А.Данилов (1930, 1932–33), М.Ш.Ишаева (1931–32, 1934), З.Ш.Таһиров (1933–36), Г.В.Кәримов (1936–41); Тарихи архив — А.В.Волочков (1928–34), В.М.Нецветаев (1934), В.Г.Бебешко (1934–35), М.Н.Олимпова (1935–41); Татарстан Республикасы МА — М.Н.Олимпова (1941–54), М.Б.Кочурова (1954–58), Г.С.Хөснетдинов (1958–61), М.Е.Козлова (1961–63), Т.А.Степанова (1963–68), А.П.Барков (1968–72), А.Ж.Җиһаншин (1972–86), Л.В.Горохова (1988– 2015), В.П.Козлов (2015 тән).

*Әд.:* Национальный архив Республики Татарстан: Путеводитель. К., 1999. Шарафутдинов Д. 85 лет государственной архивной службе Республики Татарстан // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2003. № 1/2; Горохова Л. История традиционной культуры народов Поволжья в документах Национального архива Республики Татарстан // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2006. № 1.

*Р.Г.Шәмсетдинов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ МИНИ́СТРЛАР КАБИНЕТЫ** (ТР МЌ), 1991 елның июленнән ТР дәүләт хакимиятенең югары башкарма һәм идарә органы (респ-ка хөкүмәте). ТР Президенты тарафыннан (1995 кә кадәр — ТР ЮС, 1995–2002 дә ТР Дәүләт Советы б-н килешенеп) ТР Премьер-министры (ТР Дәүләт Советында раслана), аның беренче урынбасарлары, урынбасарлары, министрлар, дәүләт ком-ты рәисләре һ.б. идарә итү органнары җитәкчеләре составында оештырыла. Башлангыч чорда — 27, 1996 дан — 33, 1998 дән — 36, 2001 дән — 23, 2005 тән — 22, 2016 дан — 30 әгъзадан тора. Респ-ка вәкаләтендәге мәсьәләләр б-н идарә итә; бюджет проектларын, социаль-икътисади үсеш программасын эшли һәм аларның үтәлешен тәэмин итә; респ-ка милке б-н идарә итә; тышкы икътисади эшчәнлекне тормышка ашыра; министрлык һәм ведомстволар эшен оештыра һәм аларга юнәлеш бирә; җирле үзидарә органнары һәм вазифаи затларына алар тарафыннан хокук актларын законга туры китерүне тәкъдим итәргә хокуклы; федераль башкарма хакимият органнары б-н килешүләр төзи һ.б. ТР МКның төп актлары — карарлар һәм боерыклар. ТР Президентына буйсына. Үз эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре буенча ТР Дәүләт Советы каршында хисап тота.

Премьер-министрлар: М.Г.Сабиров (1991–95), Ф.Х.Мөхәммәтшин (1995–98), Р.Н.Миңнеханов (1998–2010), И.Ш.Халиков (2010 нан) .

Ш.у.к. *Татарстан АССР Министрлар Советы, Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары, Татарстан Республикасы министрлыклары.*

Чыг.: Конституция Республики Татарстан. К., 1992; Закон Республики Татарстан «О внесении изменений и дополнений в Конституцию Республики Татарстан» от 19 апреля 2002 г. // Респ. Татарстан. 2002. 30 апр.; Закон Республики Татарстан «Об исполнительных органах государственной власти Республики Татарстан» от 24 марта 2005 г. // Респ. Татарстан. 2005. 7 апр.

*Е.Б.Долгов, Р.И.Тарнапольский.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ МИНИ́СТРЛЫКЛАРЫ**, респ-каның башкарма хакимияте оешмалары, хуҗалык һәм идарә эшләренең аерым тармаклары б-н җитәкчелек итәләр. СССРның 1946 ел 15 март Законы, ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы, РСФСРның 1946 ел 25 июнь Законы, ТАССР ЮСның 1946 ел 19 июль карары нигезендә *Татарстан АССР Халык комиссариатларыннан* үзгәртелә. ТР М.ның һәрберсенең төп бурычы — халык хуҗалыгының үзенә йөкләтелгән тармагының эшен, социаль-мәдәни төзелеш һәм адм.-сәяси тармаклар эшчәнлеген тәэмин итү. Моннан тыш аларга ш.у. тармакара идарә итү функцияләре дә йөкләнергә мөмкин. ТР М.тармак эшчәнлеге нормативларын җайга салалар һәм эшчәнлеген фаразлыйлар, үз карамагындагы пр-тие, оешма һәм учреждениеләр эше өчен уңайлы шартлар тудыралар, аларның эшчәнлеген көйлиләр һәм күзәтчелектә тоталар. ТР М.ның хокук дәрәҗәсе ТР Конституциясе б-н билгеләнә, аларның вәкаләтләре һәм компетенцияләре респ-ка хөкүмәтенең аерым министрлыкка караган нигезләмәсендә раслана. ТР М.ын гамәлдән чыгару, яңаларын оештыру ТР Президенты тарафыннан ТР Дәүләт Советы (1995 елга кадәр — ТР ЮС, 1995 тән — ТР Дәүләт Советы) б-н килешенеп эшләнә. ТР М. эшчәнлеге ТР МК (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР МС) тарафыннан берләштерелә һәм юнәлеш ала. Президентка һәм ТР хөкүмәтенә буйсыналар. Министрлар ТР Президенты тарафыннан (2002 гә кадәр — ТР Дәүләт Советы, элегрәк — ТР МС рәисе тәкъдиме буенча ЮС б-н килешенеп) билгеләнә һәм азат ителә. Татарстанда эшләгән

һәм эшләп килүче министрлыклар: Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек (1946 дан), Азык-төлек сәнәгате (1946–85), Гаиләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау (1992–2001), Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр (1996 дан), Дәүләт куркынычсызлыгы (1946–53), Җиңел сәнәгать (1946–59), Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр (2001 дән), Җирле сәнәгать (1946–89), Икътисад (1996 дан), Ит-сөт сәнәгате (1946–50), Матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр (1991–2001), Мәгариф һәм фән (1946 дан), Мәгълүматлаштыру һәм элемтә (1993 тән), Мәдәният (1953 тән), Мелиорация һәм су хуҗалыгы (1968–89), Сәламәтлек саклау (1946 дан), Сәнәгать һәм сәүдә (1946 дан), Социаль яклау (1946–2007), Терлекчелек (1946–47), Торак-коммуналь хуҗалык (1946–89), Төзелеш, архит-ра һәм торак-коммуналь хуҗалык (1996 дан), Транспорт һәм юл хуҗалыгы (2001 дән), Тышкы икътисади элемтәләр (1991–97), Урман сәнәгате (1948–55), Урман хуҗалыгы (1979–2001), Финанс (1946 дан), Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү (1966–96), Хезмәт һәм мәшгульлек (2001–07), Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау (2007 дән), Экология һәм табигый байлыклар (2001 дән), Эчке эшләр (1946 дан), Энергетика (2010–12), Юстиция (1946 дан), Ягулык сәнәгате (1966–88), Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм (2001–2014), Яшьләр эшләре һәм спорт (2014 тән) министрлыклары.

*Әд.:* Х а ф и з о в Ш.Ш. Развитие советской государственности татарского народа. К., 1966; Т а р н а п о л ь с к и й Р.И. Система центральных органов государственного управления автономной республики по Конституции Татарской АССР // Конституционное законодательство и государственное управление. Свердловск, 1977.

*Е.Б.Долгов, Р.И.Тарнапольский.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ МӨСЕЛМАННАРЫНЫ́Ң ДИНИЯ́ НӘЗАРӘТЕ́** (ТРМДН), ТРда теркәлгән мөселман оешмалары һәм руханиларның эшчәнлеге б-н идарә итүче дини оешма. ТРМДН 1992 елның августында Чаллы шәһәрендә узган ТРның мөселман оешмалары рәисләре съездында оештырыла, шунда ук мөфти сайлана — Г.С.*Галиуллин* (1998–2011 дә — Г.Г.*Исхаков*, 2011–13 тә И.Ә.Фәизов, 2013 тән К.И.Сәмигуллин). ТРМДНнең оешуына күп кенә шартлар этәргеч бирә: илдә барган демократлашу һәм суверенлашу хәрәкәте, ш.у. СССРның таркалуы Россиянең рәсми дини ин-тларында мөһим үзгәрешләр китереп чыгара. 1990 ның 30 августында «Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт суверенитеты турында декларация» кабул ителгәннән соң, татар милли хәрәкәте Дикия нәзарәтен Татарстан суверенлыгының татар милләтен берләштерүгә хезмәт итүче мөһим атрибуты итеп карый башлый. ТРМДН 1995 кә кадәр конфессиональ булудан бигрәк сәяси оешма була, хакимияткә оппозициядә тора. 1998 дәге съездан соң, мөселман бергәлеге һәм аның ин-тлары, ш.и. дини мәгариф б-н идарә итү системасының вертикаль структурасы ныгый. ТРМДН составына уку-укыту, фән, стат., вәгазь-нәсыйхәт, архит-ра, вакыфлар, матбугат үзәге, халыкара элемтәләр бүлекләре керә, «Идел-хаҗ» департаменты оештырыла. Район имам-мөхтәсибләре б-н эшләүче 46 мөхтәсибәт төзелә. ТРМДНндә дини-мәхкәмә хакимлеге Үзәк, Көнчыгыш, Көньяк-Көнчыгыш, Көньяк-Көнбатыш, Төньяк, Көньяк казыятлардагы җитәкчеләр һәм район казыйлары тарафыннан башкарыла. ТРМДН — Идел буе мөселман оешмаларын берләштерүче «Казан мөфтияте» мөселман дини оешмалары ассоциациясен гамәлгә куючы. Рәисе — Татарстан мөфтие. 2014 ел башында ТРМДН карамагында 1500 дән артыграк мөселман оешмасы исәпләнә. Ассоциация «*Иман нуры*», «*Ислам нуры*», «*Дин вә мәгыйшәт*», «Дин вә әдәп» һ.б. газета-журналларны нәшер итә. 2013 тән ТРМДН каршында «Хозур» нәшрият йорты ачыла. Оештыручыларның берсе — Россия ислам ун-ты.

*Әд.:* М у х а м е т ш и н Р.М. Ислам в общественно-политической жизни Татарстана в конце XX века. К., 2000; Н а б и е в Р.А. Ислам и государство. К., 2002; Государственно-конфессиональные отношения в современном Татарстане. К., 2003; Я к у п о в В.М. Ислам сегодня. К., 2011.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ́**, Татарстан Респ-касының дәүләт башлыгы, иң югары вазифаи зат. ТР П. вазифасы ТССРның «Татарстан ССР Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр турында» 1991 ел 18 апрель һәм «Татарстан ССР Президентын сайлау турында» 1991 ел 13 май Законнары нигезендә гамәлгә кертелә. ТР П. гомуми, тигез һәм туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү юлы б-н сайлана. 2005–15 елларда РФ Президенты тәкъдиме буенча биш елга ТР П. вәкаләтләре йөкләтелү ТР Дәүләт Советы тарафыннан тавыш бирү юлы б-н тормышка ашырыла (ТР Дәүләт Советы депутатларының тулы составының яртысыннан артыгы тавыш биргән очракта гына әлеге мәсьәлә буенча карар кабул ителә). ТР Конституциясе, ТРның ТРда дәүләт хакимияте башкарма органнары турында 2005 ел 6 апрель һәм 2007 ел 9 гыйнвар законнары нигезендә ТР П. респ-када кеше хокукларын һәм ирекләрен яклау, респ-каның иҗтимагый иминлеген һәм терр. бөтенлеген, аның терр-ясендә законлылыкны һәм хокук тәртибен тәэмин итә; ТР дәүләт хакимияте башкарма органнары системасына җитәкчелек итә һәм аларның ТР Дәүләт Советы б-н үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә; ТР МК эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аны отставкага җибәрү турында карар кабул итә; Татарстанның эчке һәм тышкы сәясәтен, сәяси эшчәнлек юнәлешләрен билгели; ТР Дәүләт Советына карау һәм раслау өчен ел саен ТР бюджеты һәм аның үтәлеше хакында закон проектын, ТРның берләштерелгән бюджет проектын карауга кертә, Татарстанның социаль-икътисади үсеше программаларын һәм аларның үтәлеше турында хисаплар тәкъдим итә; респ-каның сәяси тормышына, социаль-икътисади һәм мәдәни үсеш халәте һәм перспективаларына багышланган еллык Юллама б-н ТР Дәүләт Советына мөрәҗәгать итә; ТР МКын төзи, ТР Дәүләт Советына ТР Премьер-министры кандидатурасын раслау турында тәкъдимнәр кертә, ТР Дәүләт Советы б-н килешүле нигездә Премьер-министр урынбасарларын билгеләп куя; ТР министрларын һәм башкарма хакимиятнең башка органнары җитәкчеләрен (ш.и. РФнең субъектларга тапшырылган аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыручыларны) билгели, ТР Премьер-министрын, ТР МК әгъзаларын һәм ТР башкарма хакимияте органнары җитәкчеләрен, РФнең субъектларга тапшырылган аерым вәкаләтләрен үтәүчеләрне вазифаларыннан азат итә; ТР министрлыкларын һәм дәүләт ком-тларын төзү һәм гамәлдән чыгару турында тәкъдимнәр кертә; ТР терр-ясендә дәүләт хакимиятенең башкарма органнары системасын төзи һәм аларның структурасын билгели ; ТР Дәүләт Советына ТРда Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазифасына кандидатура тәкъдим итә; ТР Үзәк сайлау комиссиясе әгъзалары составыннан яртысын билгели; ТР Прокуроры вазифасына кандидатураны килештерә; дәүләт хакимиятенең федераль органнары, РФ субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары б-н мөнәсәбәтләрдә һәм халыкара тышкы икътисади бәйләнешларны гамәлгә ашырганда респ-ка исеменнән эш йөртә һәм ТР исеменнән халыкара килешүләргә, шартнамәләргә имза сала; РФда, аның субъектларында һәм чит дәүләтләр адм.-терр. берәмлекләрендә, ш.у. чит дәүләтләрдә һәм халыкара оешмаларда ТР вәкилләрен билгеләп куя һәм чакыртып ала; ТР гражданлыгы мәсьәләләрен хәл итә; законнарга кул куя яки кире кага һәм аларны ТР Дәүләт Советына кабат карау өчен кире кайтара; ТР МК карарларын һәм күрсәтмәләрен юкка чыгара; ТРның Дәүләт бүләкләре б-н бүләкли; ТР премияләрен гамәлгә куя һәм аларны тапшыра; ТРда ярлыкау мәсьәләләрен карау комиссиясен төзи; ТР башкарма хакимият органнарының респ-кадагы башка дәүләт хакимияте органнары б-н эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итә һәм ТР башкарма хакимият органнарының федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның терр. органнары, җирле үзидарә органнары һәм җәмгать берләшмәләре б-н хезмәттәшлеген оештыра; ТР Дәүләт Советы һәм аның Президиумы эшендә катнашырга хокуклы; башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра. ТРда Президент хакимияте символы булып ТР П. Штандарты (флагы) тора. Үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен, ул Президент Аппараты төзи. ТР П.ның намусы һәм абруе закон б-н саклана. ТР П.ның норматив актлары — указлар һәм күрсәтмәләр — Татарстан терр-ясендә катгый рәвештә үтәлергә тиеш. ТР П. респ-ка башлыгы буларак үз вазифаларын вакытлыча үти алмаган очракта, аларны ТР Премьер-министры башкара. ТР П.ның вәкаләтләре ул үз теләге б-н отставкага киткәндә, ТР Дәүләт Советы аңа ышанычсызлык белдерүгә (карар депутатларның билгеләнгән санынннан кимендә өчтән беренең инициативасы буенча депутатларның билгеләнгән санынннан өчтән икесе тавышы б-н кабул ителә) бәйле рәвештә РФ Президенты тарафыннан үз вазифасыннан читләштерелгәндә, феде-

раль законда каралган башка очракларда вакытыннан алда туктатыла. ТР Президентлары — М.Ш.Шәймиев (1991–2010 ), Р.Н.Миңнеханов (2010 нан) .

*Б.Л.Железнов, Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ́ КАРШЫНДАГЫ́ ДӘҮЛӘ́Т ХЕЗМӘТЕ́ ИНСТИТУТЫ́**. 2001 елда Казанда Дәүләт хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге җирлегендә ачыла. Ф-тлары: дәүләти һәм муниципаль идарә (шул исемдәге белгечлек б-н), яңадан әзерләү (югары белем базасында шул ук белгечлек), квалификация күтәрү; 2004/05 уку елыннан икътисад («финанс һәм кредит» белгечлеге). Кафедралар: социаль-икътисади процесслар б-н дәүләт идарәсе, икътисад, хокук, тарих һәм политология, социол. һәм филос., лингвистика, мәгълүмати технологияләр б-н идарә. Институт составында — мәгълүмат-аналитика бүлеге, кадрлар консалтингы һәм социол. үзәкләре. 2004 тә 207 студент көндезге бүлектә, 247 студент читтән торып уку бүлегендә укый; Пед. коллективта 24 кеше эшли (ш.и. 4 фән. д-ры, 19 фән. канд., 1 ТРның атказ. фән. эшлеклесе), читтән килеп укытучылар 118 (ш.и. 11 фән. д-ры һәм 62 фән. канд.). Ел саен якынча 500 кеше квалификациясен күтәрә. 2010 нан Казан ун-ты структурасына керә.

*Әд.:* В Казани готовят госслужащих // Научный Татарстан. 2003. № 2.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ САНИТАРИ́Я-ЭПИДЕМИОЛО́ГИЯ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ́ ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**. ТАССР ЮСның 1991 ел 29 ноябрь карары нигезендә оештырыла. Сан.-эпид. күзәтчелеге һәм халыкны төрле авырулардан кисәтү эшчәнлеге б-н шөгыльләнә. Сан.-эпид. хезмәтен оештыру һәм үстерү, эпид. күзәтчелеге, хезмәт гигиенасы, туклану гигиенасы, балалар һәм яшүсмерләр гигиенасы, коммуналь гигиена, финанс-икътисад, кадрлар әзерләү һәм эштә куллану, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр бүлекләрен; санитар нормалар бүлекчәсен берләштерә. Дәүләт ком-тына респ-ка, шәһәр, районара (зона), район дәүләт сан.-эпид. күзәтчелеге үзәкләре керә. ТР Президентына, ТР МКна һәм үз тармагындагы РФ Дәүләт ком-тына буйсына. ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май карары нигезендә эшчәнлеге туктатыла, вазифалары «Татарстан Республикасындагы дәүләт сан.-эпид. күзәтчелеге үзәге» федераль дәүләт учреждениесенә тапшырыла. Рәисе — В.В.Морозов (1991–2001).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕ́К САКЛА́У МИНИ́СТРЛЫГЫ**. тарихы Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна советының 1918 ел 26 апрель карары нигезендә Казан Совет Эшче-Крәстиян Респ-касы Сәламәтлек саклау комис-ты оештырылудан башлана; Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советы Казан губерна башкарма ком-тының 1918 ел 16 май һәм Казан губернасы ХКСның 1918 ел 3 июнь карарлары б-н — Казан губерна Сәламәтлек саклау комис-ты, Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы Казан губерна башкарма ком-тының 1918 ел 15 октябрь карары б-н — губерна башкарма ком-тының Сәламәтлек саклау бүлеге, РСФСР БҮБК һәм ХКСның 1920 ел 27 май һәм ТАССР ҮБКның 1920 ел 28 сентябрь карары б-н ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-ты итеп үзгәртелә. Халык комис-ты халыкка мед. ярдәме күрсәтү, сан. эше, эпидемияләргә каршы көрәш, аналар һәм балалар сәламәтлеген саклау юнәлешендә оештыру мәсьәләләре, Татарстандагы мед. учреждениеләре һәм аптекаларга җитәкчелек итү эше б-н шөгыльләнә. Аның составына 1920 елдан – дәвалау, сан.-эпид., аналар һәм сабыйлар сәламәтлеген саклау, балалар сәламәтлеген саклау, фарм., мәхкәмә медицинасы, стат., тәэминат; 1921 дән — мед. уку йортлары һәм мед. персоналы, хәрби-сан., смета-финанс, табиблек экспертизасы һәм контроль бүлекләре, гомуми бүлек, адм. төркем, 1941 дән эвакогоспитальләр бүлеге керә. ТАССР ҮБКна (1938 гә кадәр), ТАССР ХКСна һәм РСФСРның шул ук исемдәге ХКСна буйсына.

ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы б-н ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-ты ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгы итеп үзгәртелә (1990 нан — ТССР, 1992 дән — ТР С.с.м.). Министрлык халык сәламәтлеген саклау өлкәсендә дәүләт сәясәте үткәрүне һәм җитәкчелек итү эшен башкара. Мед. ярдәме күрсәтү, аналар һәм балалар сәламәтлеген саклау, мед. ярдәме күрсәтүне үстерү, мед. ярдәме күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм тармак буенча стандартлаштыру, халыкны авыру очракларыннан кисәтү, фарм. һәм мед. техникасы, мед. иминияте һәм бюджеттан тыш финанслау бүлекләрен берләштерә. Министрлык системасына хастаханәләр һәм амбулатория-поликлиника учреждениеләре (ш.и. Төбәкара клиник диагностика үзәге, 1 нче һәм 2 нче Респ-ка клиник хастаханәләре, Респ-ка балалар клиник хастаханәсе һ.б.), диспансерлар, бала тудыру йортлары, ашыгыч мед. ярдәме күрсәтү станцияләре һәм бүлекләре, сабыйлар йортлары, балалар санаторийлары, сөт кухнялары, мед. профилактикасы үзәкләре, кан бирү станцияләре һәм бүлекләре, фельдшер-акушерлык пунктлары һ.б. керә. ТР Президентына, ТР МКна (1991 гә кадәр — ТАССР МС) һәм үз тармагындагы РФ Министрлыгына буйсына.

Халык комиссарлары һәм министрлар: К.Г.Мохтаров (1920–1921, июнь), Ш.Г.Гайнетдинов (1921, июль–дек.), К.М.Стацинский (1921, дек. – 1922), Ф.Г.Мөхәммәдьяров (1922–27), С.Б.Еналиев (1927–28), К.Х.Мәһдиев (1928–30), С.Х.Моратов (1930–31), С.М.Корбангалиев (1931–35), И.И.Беганский (1935–37), Б.Г.Кәбиров (1937–38), Б.С.Гинзбург (1938–40), Х.Н.Латыйпов (1940–42), В.И.Прокушев (1942–49), Н.А.Абрамов (1950–52), Г.Ф.Тихонов (1952–54), М.И.Грачёв (1954–59), Р.Ю.Ярмөхәммәтова (1959–64), И.З.Мөхетдинов (1964–84), В.К.Кириллов (1984–86), А.Д.Царегородцев (1986–88), Р.У.Хәбриев (1988–94), К.Ш.Зыятдинов (1994–2007), А.З.Фәррахов (2007–2013), Г.Ю.Вафин (2013 тән). Ш.у.к. *Сәламәтлек саклау, Медицина*.

*Әд.:* П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ СӘНӘГА́ТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**. Тарихы ТАССР ХКС Икътисади киңәшмәсе (ЭКОСО) каршында Эчке сәүдә комиссиясе (ТАССР ХКС Икътисади киңәшмәсенең 1923 ел 29 нояб. карары нигезендә) төзелүдән башлана. Эчке сәүдә комиссиясе СССР ҮБК һәм ХКСның 1924 ел 9 май һәм БҮБК һәм РСФСР ХКСның 1924 ел 22 декабрь карарлары б-н — ТАССР Эчке сәүдә халык комис-ты, ТАССР ҮБК һәм ХКСның 1927 ел 24 гыйнвар карары б-н ТАССР Сәүдә халык комис-ты итеп үзгәртелә, ТАССР ҮБК һәм ХКСның 1931 ел 4 гыйнвар карары б-н гамәлдән чыгарыла (вазифалары ТАССР Тәэминат халык комис-тына тапшырыла), ТАССР ҮБК Президиумының 1934 ел 29 август карары б-н — ТАССР Эчке сәүдә халык комис-ты, ТАССР ҮБК Президиумының 1938 ел 3 февраль карары б-н ТАССР Сәүдә халык комис-ты буларак кабат торгызыла. Сәүдә сәясәтен җитәкли, эчке сәүдә әйләнешен көйли, эчке базар һәм дәүләт сәүдәсе үсешенә булышлык итә, финанс, кредит һәм сәүдә статистикасын оештыру мәсьәләләрен хәл итә, халыкны икмәк б-н тәэмин итә, азык-төлек һәм көнкүреш товарлары, чимал һәм кыйммәтле җәнлек тиреләре әзерләүне оештыра; 1930 еллардан тулаем җитәкчелек, җирле сәүдә һәм уку йортлары эшчәнлеген көйләү һәм тикшереп тору, товар әйләнешен планлаштыру һәм җәелдерү, бәяләр билгеләү буенча чаралар күрү һ.б. аңа йөкләнә. 1920 елларда – эшләр башкару идарәсен, планлаштыру-икътисад, стат. һәм икътисад, а.х. продуктларын әзерләүне көйләү, сәүдә инспекциясе, тәэминат, сәнәгать товарлары, кадрлар бүлекләрен, бухгалтерияне; 1930–40 елларда адм.-хуҗалык, азык-төлек товарлары, сәнәгать товарлары, сәүдәне оештыру, планлаштыру-икътисад, җәмәгать туклануы, колхоз сәүдәсе, кадрлар бүлекләрен ; бәяләр, җиләк-җимеш һәм яшелчә секторларын; бухгалтерияне; контроль-исәп бюросын; ярдәмче хуҗалык б-н идарә итү төркемен үз эченә ала. Халык комис-ты эчке сәүдә буенча кантон вәкилләрен (1930 га кадәр), 70 район һәм 3 шәһәр сәүдә бүлеген (1930–40 елларда), 84 торгны берләштерә. ТАССР ҮБКна, ТАССР ХКСна һәм РСФСРның шул ук исемдәге Халык комис-тына буйсына.

ТАССР Сәүдә халык комис-ты ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы б-н ТАССР (1990 нан — ТССР, 1992 дән — ТР) Сәүдә министрлыгы, ТР Дәүләт Советының 1996 ел 25 апрель карары б-н — ТР Кулланучылар һәм сәүдә министрлыгы, ТР Дәүләт Советының 1998 ел 21 декабрь карары б-н — ТР Икътисади хезмәттәшлек һәм сәүдә министрлыгы, ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май карары б-н — Сәүдә һәм тышкы икътисади хезмәттәшлек министрлыгы, ТР Президентының 2007 ел 10 июль Указы б-н ТР С.һ.с.м. итеп үзгәртелә. Министрлык

планлаштыру, сәүдәне оештыру һәм көйләү б-н шөгыльләнә, сәүдә итүче пр-тиеләр эшен контрольдә тота; 1990 еллар уртасыннан кулланучылар базары, сәүдә, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү, икътисади хезмәттәшлек өлкәсендә дәүләт сәясәте алып бара. 21 йөз башында тышкы сәүдә эшчәнлеге б-н идарә итә, эчке сәүдә базарының товарлар һәм хезмәт күрсәтү б-н тәэмин ителешен көйли; 2007 дән сәнәгать һәм кулланучылар базары өлкәсендә, халыкара, төбәкара һәм тышкы икътисади бәйләнешләр б-н идарә итүдә дәүләт сәясәте үткәрә. 1940–60 елларда Министрлык составына – адм.-хуҗалык, планлаштыру-финанс, сәүдә, җитештерү-технол., сәүдәне оештыру, җәмәгать туклануы, кадрлар бүлекләре; хәзерләүләр, бәяләр, икмәк һәм икмәк продуктлары б-н сәүдә итү секторлары; 1970–80 елларда — гомуми, планлаштыру-икътисад, азык-төлек товарлары сәүдәсе, сәнәгать товарлары сәүдәсе, финанс, бухгалтер исәп-хисабы, контроль һәм ревизия, капиталь төзелеш, сәүдәне оештыру, кадрлар бүлекләре; яңа техниканы куллanышка кертү, хезмәтне фәнни оештыру, икътисади мәгълүмат һәм сәүдә конъюнктурасы лаб-яләре; укыту-методика кабинеты; архив; 21 йөз башында — халыкара тышкы икътисади бәйләнешләрне координацияләү, төбәкара хезмәттәшлекне координацияләү, презентация чаралары, рәсми беркетмәләр, рәсми тәрҗемәләр, базарны яклау, продукция һәм хезмәт күрсәтүне тәкъдим итү, сәүдә йортларына аудит уздыру һәм вәкиллекләр челтәре, маркетинг, продукция һәм хезмәт күрсәтү логистикасы үсеше, күргәзмә чараларына ярдәм, чит ил инвестицияләре катнашындагы проектларны координацияләү, экспорт программаларын яклау һәм эчке икътисади эшчәнлекне анализлау, федераль программаларны тормышка ашыру, халыкара икътисади оешмалар б-н хезмәттәшлекне координацияләү, махсус икътисади зона б-н эшләү; бюджетны планлаштыру һәм финанс, хокук, кадрлар һәм кадрлар сәясәте; гомуми, бинаны тоту бүлекләре; икътисади куркынычсызлык, электрон документ әйләнеше, дәүләт заказы секторлары; 2007 дән — машина-төзелеше комплексы; оборона комплексы; сәнәгатьнең тармак идарәләре; сәнәгать һәм сәүдәнең кадрлар потенциалын анализлау; эшмәкәрлекне үстерү; инвестиция эшчәнлеге; инновацион эшчәнлек; энергетика комплексы һәм энергетика ресурсларын саклау; нефть эшкәртү һәм нефть химиясе комплекслары; нефть чыгару комплексы; газ инфраструктурасын үстерү һәм җылылык-энергетика ресурслары б-н тәэмин итү; БДБ илләре б-н халыкара икътисади бәйләнешләр һәм хезмәттәшлекне координацияләү; рәсми беркетмәләр; тәрҗемәләр; респ-ка һәм федераль экспортны үстерү һәм эчке икътисади эшчәнлек анализы программалары; халыкара финанс оешмалары б-н хезмәттәшлекне координацияләү; РФ төбәкләре б-н хезмәттәшлекне координацияләү һәм сәүдә йортларын үстерү; кулланучыларга хезмәт күрсәтү базарын үстерү һәм анализлау; сәүдә, көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм җәмәгать туклануын үстерү программаларын тормышка ашыру; күргәзмә эшчәнлеген планлаштыру; сәнәгать һәм кулланучылар базарының стратегик үсеше һәм маркетинг; җитештерү-хуҗалык эшчәнлеге аудиты; мәгълүмати технологияләрне үстерү; сәнәгать һәм кулланучылар базары икътисади анализы; оештыру эшләре; эшләр башкару; гомуми; мәгълүмати материаллар һәм презентация чаралары әзерләү; мобилизация эшләре; хокук; финансларны планлаштыру, исәп-хисап; кадрлар; сыйфат менеджменты системасы бүлекләре; дәүләт заказы секторы керә. 1980 елларда Министрлык системасында 2 шәһәр идарәсе, 43 район һәм шәһәр сәүдә бүлеге, 3,5 меңгә якын пр-тие исәпләнә. ТР Президентына, ТР (1991 гә кадәр — ТАССР МС) МКна һәм РСФСРның шул ук исемдәге министрлыгына буйсына.

Халык комиссарлары һәм министрлар: А.Н.Злобин (июнь–окт., 1924), В.И.Исхаков (окт., 1924–1926), В.Н.Ануфриев (1926–27), И.М.Бажанов (1927–гыйн., 1930), В.Н.Никольский (гыйн.–нояб., 1930), Н.И.Анцишкин (нояб., 1930–1931), М.И.Залинский (1934–36), Н.М.Скоморовский (1936–37), Е.П.Павлова (1937–38), Д.В.Павлов (1938–39), Г.Л.Әхмәдуллин (1939–40), М.М.Архипов (1940–42), П.А.Щелчков (1942–43), И.Я.Морозов (1943–44), Х.Х.Мөхәммәтҗанов (1944–47), В.А.Чванов (1947–56), М.М.Талантов (1956–58), М.И.Исмәгыйлев (1958–62, 1964–67), М.Ш.Шакиров (1962–64), И.А.Ташбулатов (1967–79), Ф.Б.Баһаветдинов (1979–87), Р.Ф.Моратов (1987–89), Ф.Х.Мөхәммәтшин (1989–90), А.И.Нуруллин (1990–96), А.И.Конюшева (1996–97), И.З.Тимергазиев (1997–98), Х.М.Салихов (1998–2007), А.А.Когогин (2007–2009), Р.Х.Зарипов (2009–15), А.Ә.Кәримов (2015 тән). Ш.у.к. *Сәнәгать, Сәүдә.*

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ СӘҮДӘ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ СӘҮДӘ́ ҺӘМ ИКЪТИСАДИ́ ХЕЗМӘТТӘШЛЕ́К МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ СӘҮДӘ́ ҺӘМ КУЛЛАНУЧЫЛАРГА́ ХЕЗМӘ́Т КҮРСӘТҮ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ СӘҮДӘ́ ҺӘМ ТЫШКЫ́ ИКЪТИСАДИ́ ХЕЗМӘТТӘШЛЕ́К МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ СОЦИА́ЛЬ ТӘЭМИНА́Т МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасы Социаль яклау министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ СОЦИА́ЛЬ ЯКЛА́У МИНИ́СТРЛЫГЫ**. Тарихы Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна советы гомуми җыелышының 1918 ел 26 февраль карары нигезендә Казан Совет Эшче-Крәстиян Респ-касының Җәмәгать тәрбиясе комис-ты оештырылудан башлана. Казан Совет Эшче-Крәстиян Респ-касы ХКСның 1918 ел 2 апрель карары нигезендә — респ-ка дәүләт тәэминат комис-ты, Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советы Казан губерна башкарма ком-тының 1918 ел 16 май һәм Казан губерна ХКСның 1918 ел 3 июнь карарлары нигезендә — Казан губерна дәүләт тәэминат комис-ты, Казан губерна рев.ком-тының 1918 ел 12 сентябрь һәм Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы Казан губ. башкарма ком-тының 1918 ел 15 октябрь карарлары нигезендә — губерна башкарма ком-тының социаль тәэминат бүлеге, Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы Казан губерна башкарма ком-тының 1918 ел 29 ноябрь карары нигезендә — губерна башкарма ком-тының хезмәт һәм социаль тәэминат бүлеге, БҮБКның 1920 ел 21 апрель карары нигезендә — кабат губерна башкарма ком-тының социаль тәэминат бүлеге, БҮБК һәм РСФСР ХКСның 1920 ел 27 май Декреты һәм ТАССР ҮБКның 1920 ел 28 сентябрь карары нигезендә — ТАССР Социаль тәэминат халык комис-ты, ТАССР ҮБКның 1927 ел 25 март карары нигезендә ТАССР Хезмәт һәм социаль тәэминат халык комис-тының социаль тәэминат бүлеге итеп үзгәртелә. ТАССР ҮБКның 1928 ел 6 октябрь карары нигезендә ТАССР Социаль тәэминат халык комис-ты итеп кабат торгызыла. Халык комис-ты инвалидлар һәм өлкәннәрне дәүләт тарафыннан тәэмин итү б-н шөгыльләнә, социаль тәэминат учреждениеләрен җитәкли, хәерчелек, сукбайлык, фахишәлек б-н көрәш, аналар һәм балаларны яклау чараларын әзерләү һәм үткәрүдә, инвалидларга һөнәри белем бирүдә катнаша. Башлангыч чорда Халык комис-ты составына пенсия һәм пособиеләр; инвалидлар учреждениеләре; контроль-инструкторлык ; финанс-хуҗалык; гомуми (адм.-оештыру); бухгалтерия һ.б. бүлекләр керә. 1945 тән пенсия б-н тәэмин итү; инвалидлар йортлары; хезмәткә өйрәтү һәм эшкә урнаштыру; колхозчыларның үзара ярдәм җәмәгать кассалары; планлаштыру; адм.-хуҗалык бүлекләре эшли. Халык комис-ты карамагында кантон (1930 га кадәр), район, шәһәр социаль тәэминат бүлекләре; сугыш һәм хезмәт инвалидлары, балалар өчен 13 интернат; мед.-хезмәт эксперт комиссияләре; крәстияннәр үзара ярдәм җәмгыятьләренең Татарстан ҮК (1931 гә кадәр); Татарстан инвалидлар кооперациясе берлеге; Татарстан сугыш инвалидларына, авыру, яралы һәм демобилизацияләнгән кызылармиячеләргә, сугышта һәлак булганнарның гаиләләренә һәм хәрбиләр гаиләләренә ярдәм итү җәмгыяте; Сукырлар җәмгыяте һәм Чукраклар җәмгыятенең Татарстан бүлекләре; Казан һөнәри интернат — мәктәп; совхоз; Казан протез з-ды һәм 1938 гә кадәр Казандагы пр-тиеләр: мамык, фетр, агач эшләнмәләр — караватф-калары, көпчәк мае з-ды, 8 чәчтарашханә була. ТАССР ҮБКна (1938 гә

кадәр), ТАССР ХКСна һәм РСФСР Социаль тәэминат халык комис-тына буйсына.

ТАССР Социаль тәэминат халык комис-ты ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы нигезендә — ТАССР (1992 дән — ТР) Социаль тәэминат министрлыгы, ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май карары нигезендә ТР С.я.м. итеп үзгәртелә. Министрлык пенсия билгеләү һәм түләү; мед.-хезмәт экспертизасы оештыру; инвалидларның хезмәтен һәм көнкүрешен көйләү чаралары үткәрү һәм һөнәри белем бирү; пенсионерлар, күп балалы һәм ялгыз аналар һәм аларның гаилә әгъзаларына, картлар һәм инвалидлар йортларында яшәүче граждannarга матди-көнкүреш ярдәме күрсәтүгә җитәкчелек итә; Бөтенроссия сукырлар җәмгыяте һәм Бөтенроссия чукраклар җәмгыятенең Татарстан бүлекләре, колхозчылар һәм пенсионерларның үзара ярдәм җәмгать кассалары эшчәнлегенә юнәлеш бирә. 21 йөз башында респ-ка халкын социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыра һәм социаль яклау б-н идарә итә, башка оешмаларның балалы гаиләләрне, өлкән яшьтәге граждannarны, ветераннарны, инвалидларны, һәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән, аларны бетерүдә катнашкан граждannarны, сәяси репрессия корбаннарын һәм дәүләт ярдәменә мохтаҗларны ташламалар, гарантияләр б-н тәэмин итү, аларга социаль хезмәтләр күрсәтү буенча эшчәнлеген координацияли. Бюджетка карамаган социаль яклау юнәлешен үстерү, инвалидларга мед.-социаль экспертиза, реабилитация һәм социаль интеграция; ташламалар һәм социаль ярдәм; өлкәннәрне, инвалидларны, авыр тормыш хәленә юлыккан кешеләрне социаль яктан тәэмин итү; гаиләләргә һәм балаларга социаль ярдәм; тармак буенча программалаштыру; мәгълүмат-аналитика; планлаштыру-финанс; хуҗалык эшчәнлеге финанслары хисабы һәм контроль; хуҗалык эшчәнлеге аудиты; оештыру эшләре; хокук; кадрлар сәясәте; эш башкару; халык б-н эшләү; техник һәм хуҗалык ягыннан тәэмин итү бүлекләрен берләштерә. 1980 елларда Министрлык составына социаль тәэминатның 70 шәһәр, район һәм шәһәрләрдәге район бүлекләре; 10 ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар йорты, 2 балалар йорты; 21 йөз башында — 57 халыкка социаль ярдәм күрсәтү үзәге; 11 гаилә һәм балаларга социаль ярдәм үзәге; ветераннар, инвалидлар, өлкән яшьтәгеләр һәм балигъ булмаганнар өчен 31 реабилитация үзәге, 33 картлар һәм инвалидлар интернат-йорты, 32 балалар һәм яшүсмерләр приюты, 4 психоневрология интернаты, яшәү урыны һәм шөгыле булмаган кешеләр өчен 3 социаль адаптация үзәге, 1 социаль кунакханә керә. ТР Президентына, ТР МКна (1991гә кадәр — ТАССР МС) һәм РФнең шул ук исемдәге министрлыгына буйсына. ТР Президентының 2007 ел 14 июнь Указы нигезендә гамәлдән чыгарыла, вазифалары *Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына* тапшырыла.

Халык комиссарлары һәм министрлар: В.И.Исхаков (1920–21), С.М.Еникиев (1921–23), Г.Ф.Фәсхетдинов (1923–27), А.С.Аитов (1928–30), Х.М.Җиһаншин (1930–37), Г.Г.Измайлова (1938–39), М.Ф.Гайнетдинова (1940–46), Т.А.Белов (1946–54), С.А.Александров (1955–59), Ф.Г.Хәкимова (1959–77), М.А.Космодемьянская (1977–85), Г.П.Лоцманова (1985–96), К.Н.Новикова (1996–2007).

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ТАРИХИ́ ҺӘМ МӘДӘНИ́ ИСТӘЛЕКЛӘРНЕ́ ТОРГЫЗУ́ ФОНДЫ́**, хәйрия оешмасы. ТР Президентының 2010 ел 17 февраль Указы б-н коммерцияле булмаган оешма буларак гамәлгә кертелә. Химаячеләр советы рәисе – М.Ш.Шәймиев, башкарма директоры Т.В.Ларионова. Фондның төп максатлары: Болгар тарих-архит-ра музей-саклаулыгын, «Зөя утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архит-ра һәм сәнгать музееn, башка тарихи һәм мәдәни истәлекләрне торгызу һәм үстерү, ш.у. күпмилләтле Татарстан халкының тарихи, мәдәни һәм рухи кыйммәтләрен саклау һәм үстерү, моның өчен кирәкле финанс ресурсларын җәлеп итү. «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм «Зөя утрау-шәһәре» комплекслы проекты Д.С.Лихачёв исем. Россия мәдәни һәм табигый мирас фәнни-тикшеренү ин-ты тарафыннан эшләнә. Болгар музей-саклаулыгы һәм «Зөя утрау-шәһәре» музее терр-ясендә инфраструктура объектларын төзү, ш.у. тарихи һәм мәдәни истәлекләрне реставрацияләү буенча кабул ителергә тиешле карарларны фәннитодик нигезләү һәм аларга эксперт бәясе үткәрү максатыннан Фондның Халыкара фәнни-методик эксперт советы (рәисе И.Р.Гафуров) оештырыла. Фонд әлеге истәлекләрне ЮНЕСКО Бөтендөнья Халыкара тарихи һәм мәдәни мирас исемлегенә кертү буенча эш алып бара; археол. тикшеренүләр, ш.и. объектның бөтенлегенә зыян китермичә эшләү ысуллары (геол., авиакосмик һәм магнитлы разведкалау) б-н тикшеренү эшләрен координацияли, Болгар дәүләт тарих-архитра музей-саклаулыгы һәм «Зөя утрау-шәһәре» музее коллекцияләрен һәм музей әйберләрен реставрацияләү һәм консервацияләүгә, торгызылган объектларны музей мәнфәгатьләренә яраклаштырырга, ремонт-торгызу эшләре үткәрү һәм аерым объектлар төзүгә ярдәм күрсәтә. Фонд инвесторлар сыйфатында эре сәнәгать һәм а.х. пр-тиеләрен җәлеп итә. Инвесторлар акчасына Болгарда Ак мәчет комплексы, Икмәк музее төзелә; Идел буе Болгар дәүләтенең 922 елда рәсми рәвештә ислам динен кабул итүе уңаеннан Истәлек билгесе – түгәрәк бакыр гөмбәзе очына ярымай куелган сигез кырлы бина (төп залында дөньядагы иң зур басма Коръән китабы урнаштырылган) төзелә, килүчеләр өчен чатырлардан лагерь корыла һ.б.; Зөядә казна корылмалары комплексы (элекке казначылык йорты, кабулханәләр, төрмәләр, хастаханәләр һ.б. биналар), ш.у. «Каменев йорты» сәүдә-кунакханә комплексы, Успение монастыреның Братский, Архимандрит корпуслары һәм монастырь уч-щесе бинасы реставрацияләнә, елга вокзалы бинасы төзелә һ.б.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ТЕА́ТРЛАРЫ**. «Театр эшләрен берләштерү турында»гы 1917 ел 9 ноябрь һәм 1919 ел 26 август декретлары нигезендә Казан губернасында театрлар эшчәнлегенә күзәтчелек башта Казан шәһәр Эшче һәм солдат депутатлары советының губерна мәгариф бүлеге театр секциясенә, аннары (1919 дан) РСФСР (1920 дән — ТАССР) Мәгариф халык комис-тының театр бүлегенә йөкләнә. Төп театрлар: шәһәр театры, Казан Зур драма театры, «Алафузов театры», Яңа театр, ш.у. Дворяннар, Сәүдәгәрләр һәм Офицерлар җыеннары театрларының биналары национализацияләнә; 4 дәүләт театры (*үрнәк театрлар*) оеша: опера театры (Кызылармиячеләр сарае дип үзгәртелгән Яңа театр бинасында), Совет Зур театры (хәзер Казан Зур драма театры), Елга аръягы Эшчеләр театры (Елга аръягы Эшчеләр сарае дип үзгәртелгән элекке «Алафузов театры» бинасында), Беренче татар дәүләт театры (элекке Сәүдәгәрләр җыены бинасында). Бер үк вакытта (1924–28) хосусый театрлар (антрепризалар) да эшләүләрен дәвам итә: Д.Бедный исем. театр, Казанда «Кыеш көзге» («Кривое зеркало»), «Күңелле сатир» («Весёлый сатир») миниатюра театрлары, Чистайда Д.И.Осипов-Дальский җитәкчелегендәге драма театры һ.б. 1923–26 да Казанда «КЭМСТ театр тамашалары остаханәсе» театры оеша, ул үзенең эшләү практикасында «сул» сәнгать (к. *КЭМСТ*) принципларына таяна; 1926–28 дә Татарстан профсоюзлар берлеге советы күчмә театры эшли. Акча җитмәү сәбәпле, 1930 га Казанда 2 дәүләт театры гына кала: Татар акад. һәм Казан Зур драма театрлары. 1932 дә Үзәк пионерлар клубы каршында Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) һәм курчак театры оеша, алар шәһәр пр-тиеләре акчасына эшли. 1934 тә курчак театры Беренче дәүләт интернациональ курчак театры дип үзгәртелә, 1935 тә ТЮЗ дәүләт театры статусы ала. 1933 тә Татар акад. театрының күчмә колхоз-совхоз ф-лы оеша, аның труппасына таратылган Мәскәү үзәк татар эшче театры актёрлары керә. Бер үк вакытта авыл тамашачысына хезмәт күрсәтү максатыннан оешкан, татар һәм рус труппаларыннан торган районара (Алексеев, Әлмәт, Бөгелмә, Буа, Мамадыш, Минзәлә, Чистай) челтәре формалаша. Аларның күбесе 1930 еллар ахырына таркала һәм дәүләт театрларына үзгәртеп корыла: Бөгелмә рус драма театры (1940 тан), Әлмәт татар драма театры (1951 дән), Минзәлә татар драма театры (1957 дән). Татар акад. театрының колхоз-совхоз ф-лы 1942 дә Буа шәһәр татар драма театры дип үзгәртелә, 1944 тә Казанга күчерелә һәм Татар респ-ка күчмә театрына үзгәртелә, 1979 дан Татар дәүләт драма һәм комедия театры (1988 дән К.Тинчурин исем.) буларак эшли башлый һәм Казанда төпләнә. 1934 тә ТАССР ХКС тарафыннан опера театрын яңадан оештыру турында карар кабул ителә. Әлеге карар нигезендә Мәскәүдә татар опера студиясе ачыла, аны тәмамлаучылар 1939 да Татар дәүләт опера һәм балет театры труппасын тәшкил итәләр. Чаллы шә-

һәрендә 1987 дә — Дәүләт курчак театры, 1990 да Татар яшьләр драма театры ачыла. 1994 тә Түбән Камада – һәвәскәрләр коллективы нигезендә Шәһәр (муниципаль) яшьләр татар театры, 2007 дә Буада — Татар драма сатира театры, 2011 дә Әтнә драма театры төзелә. 1990 елларга кадәр шәһәр һәм авыл мәдәният йортлары һәм сарайлары каршында ш.у. һәвәскәр (үзешчән) театрлар зур үсеш ала (аларның күбесе халык театры исеменә лаек була). Хәзерге вакытта ТРда Татар акад. театры, Татар опера һәм балет театры, Казан Зур драма театры, Татар драма һәм комедия театры, Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ), Казан татар яшь тамашачылар театры, Татар курчак театры «Әкият», Әлмәт татар драма театры, Бөгелмә рус драма театры, Буа татар драма театры, Минзәлә татар драма театры, Чаллы татар драма театры, Чаллы курчак театры, Түбән Кама татар драма театры, Чаллы шәһәрендә «Мастеровые» рус драма театры, Әтнә драма театры эшли.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕ́Ш, АРХИТЕКТУ́РА ҺӘМ ТОРА́К-КОММУНА́ЛЬ ХУҖАЛЫ́К МИНИ́СТРЛЫГЫ**. Тарихы Казан губерна ХХС каршында (1920 дән — ТАССР ХХС каршында) ХКСның 1918 ел 9 май Декреты нигезендә оештырылган, 1918 нең 14 ноябреннән гамәлгә кергән Дәүләт корылмалары ком-тыннан башлана, Ком-т ТАССР ХКСның 1922 ел 4 март карары б-н — ТАССР ХКС Икътисади киңәшмәсе каршындагы Төзелеш архитекторлары идарәсе, ТАССР ХКСның 1924 ел 16 февраль карары б-н — ТАССР ХКС каршындагы Төзелеш инженерлары идарәсе, ТАССР ХКСның 1931 ел 28 август һәм ТАССР ҮБК Президиумының 1931 ел 24 ноябрь карары б-н — ТАССР Коммуналь хуҗалык халык комис-тының төзелеш идарәсе (1937 дән — төзелеш секторы), РСФСР ХКСның 1943 ел 21 декабрь карары һәм ТАССР ХКСның 1944 ел 20 март карары б-н — ТАССР ХКСның (1946 дан — МС) Архит-ра эшләре идарәсе, РСФСР ЮС Президиумының 1955 ел 1 декабрь Указы һәм ТАССР 1956 ел 11 февраль Законы б-н ТАССР МСның Төзелеш һәм архит-ра идарәсе итеп үзгәртелә. Идарә РСФСР ЮС Президиумының 1959 ел 14 май карары һәм ТАССРның 1960 ел 7 гыйнвар Законы б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары ТАССР Коммуналь хуҗалык министрлыгына тапшырыла, ТАССР ЮС Президиумының 1961 ел 2 сентябрь карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1961 ел 23 сентябрь Указы б-н ТАССР МСның Төзелеш һәм архит-ра идарәсе буларак кабат торгызыла, ТАССР ЮС Президиумының 1979 ел 23 август Указы б-н ТАССРның Төзелеш эшләре буенча дәүләт ком-ты итеп үзгәртеп төзелә, ТССР ЮСның 1991 ел 5 июль карары б-н — ТССР (1992 дән — ТР) Төзелеш һәм архит-ра дәүләт ком-ты, ТР Дәүләт Советының 1996 ел 25 апрель карары б-н — ТР Төзелеш һәм архит-ра министрлыгы, ТР Дәүләт Советының 1998 ел 10 февраль карары б-н — ТР Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, ТР Президентының 2002 ел 5 сентябрь Указы һәм ТР Дәүләт Советының 2002 ел 5 сентябрь карары б-н ТР төзелеш, архит-ра һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы итеп үзгәртелә. Архит-ра, шәһәр төзелеше, төзелеш, 1996 дан ш.у. төзелеш материаллары сәнәгате, 1998 дән коммуналь хуҗалык һәм торак өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыра. Элек канцелярияне, дәүләт архит-ра-төзелеш контроле инспекциясен, бухгалтерияне; шәһәрләр һәм эшчеләр посёлокларын планлаштыру һәм төзү, авыл җирлегендәге төзелеш, проект һәм сметалар экспертизасы, кадрлар бүлекләрен; 1990 еллар уртасыннан — шәһәр төзелеше сәясәте, инфраструктуралар һәм терр. үсеш, инвестиция-төзелеш баш идарәләрен; архит-ра, торак-коммуналь сәясәт, дәүләт шәһәр төзелеше кадастры, икътисад һәм инвестицияләр, капиталь төзелеш, төзелеш комплексы үсеше идарәләрен; дәүләт архит-ра-төзелеш контроле инспекциясен; ТР ведомстводан тыш экспертизасын; тендер ком-тын; инвестиция банкын; шәһәр төзелеше, лицензияләү, инженер-техник үзәкләрне; мәгълүмат, нәширият эшчәнлеге һәм кадрлар бүлекләрен; 21 йөз башында — эшләр башкару (оештыру, адм.-хуҗалык, канцелярия бүлекләре), дәүләт программаларын һәм төбәкара элемтәләрне тормышка ашыру (Үзәк, Төньяк-Көнчыгыш, Кама аръягы зоналарында дәүләт программаларын тормышка ашыру; төбәкара элемтәләр бүлекләре), торак сәясәте һәм социаль өлкә объектларыннан файдалану (торак сәясәте һәм торак базарындагы процессларны көйләү, социаль өлкә һәм торак фонды объектларын капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү, социаль өлкә һәм торак фонды объектлары б-н идарә итү һәм алардан файдалану бүлекләре); коммуналь комплекс үсеше (коммуналь комплекс үсеше, тармак программаларын координацияләү, берләштерелгән диспетчерлык хезмәте бүлекләре); икътисади фаразлау, тарифлар һәм инвестиция сәясәте (финанс һәм инвестиция сәясәте, торак-коммуналь хуҗалык икътисады һәм мониторингы, торак-коммуналь идарәдә бәяләр кулланылышына контрольлек итү бүлекләре), мөлкәти мөнәсәбәтләр (финанс-хуҗалык эшчәнлеге аудиты, дәүләт мөлкәте б-н идарә итү, пр-тиеләрне үзгәртеп кору процедураларын башкару бүлекләре); төзелеш үсеше (социаль инфраструктура һәм торак фонды объектлары төзелеше, төзелеш материаллары сәнәгате, төзелештә күзәтчелек органнары эшчәнлеген координацияләү, милли проектларның үтәлешен оештыру бүлекләре), шәһәр төзелеше сәясәте (шәһәр төзелешен планлаштыру, шәһәр төзелешен мәгълүмати-методик тәэмин итү, архит-ра бүлекләре); милли һәм респ-ка проектларын тормышка ашыру (проектларны координацияләү һәм башкару, терр-яләрне шәһәр төзелешенә әзерләү, проект документларын әзерләү бүлекләре) идарәләрен; мәгълүмат-аналитика, торак-коммуналь хуҗалык реформаларының норматив тәэмин ителеше һәм мониторингы, төзелеш һәм Түбән Кама нефть эшкәртү з-ды төзелеше һәм төзелешкә технол. ярдәм бүлекләрен үз эченә ала. Министрлык карамагында 1980–90 елларда — 55 шәһәр һәм район идарәсе һәм бүлекләре, 55 җитештерү төркеме; хәзерге вакытта 13 оешма һәм пр-тие исәпләнә. ТР Президентына, ТР МКна (1991гә кадәр — ТАССР МСна) һәм шул исемдәге РСФСР дәүләт ком-тына буйсына.

Дәүләт ком-ты рәисләре һәм министрлар: П.А.Саначин (1979–84), Р.С.Насыйров (1984–90), И.Ш.Әсәдуллин (1990–95), Н.Д.Денисов (1995–98), И.Б.Шәйдуллин (1998–2000), М.Ш.Хөснуллин (2001–10), И.Э.Фәйзуллин (2010 нан).

Ш.у.к. *Шәһәр төзелеше, Коммуналь хуҗалык, Төзелеш.* *Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕ́Ш ҺӘМ АРХИТЕКТУ́РА МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕ́Ш ҺӘМ ТОРА́К-КОММУНА́ЛЬ ХУҖАЛЫ́К МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ТРА́НСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**. ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май һәм ТР МКның 2001 ел 9 июль карарлары нигезендә оештырыла. Юл хуҗалыгы өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәрү һәм идарә эшләрен тормышка ашыра; гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын төзү, яңарту, эшчәнлеген тәэмин итү һәм ремонтлау; автомобиль, һава (гражданнар авиациясе), эчке су юллары, сәнәгать, үткәргеч торбалар һәм шәһәр электр транспорты (ш.и. метрополитен) б-н җитәкчелек итә. Юл хуҗалыгы, транспорт, хезмәт идарәләрен, финанс, хокук, оештыру, транспорт сәясәте, бәя билгеләү программалары, аудит, мәгълүмат-аналитика, автомобиль юллары, күперләр, юл төзү материаллары сәнәгате, шәһәр йөк ташу, тимер юл, су, һава һәм үткәргеч торбалар транспорты, кадрлар һәм кадрлар сәясәте, адм.-хуҗалык бүлекләрен; документлар б-н эшләү секторын; мобилизацион әзерлек, хезмәт саклау, терр. органнар һ.б. юнәлештә эшләүче баш белгечләрне үз эченә ала. ТР Президентына һәм ТР МКна буйсына .

Министрлар: В.А Швецов (2001–07), И.И.Фәсхетдинов (2007–09), Л.Р.Сафин (2010 нан).

Ш.у.к. *Транспорт, Юл-транспорт төзелеше.* *Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ТЫШКЫ́ ИКЪТИСАДИ́ ЭЛЕМТӘЛӘ́Р МИНИ́СТРЛЫГЫ**. ТРның 1992 ел 9 июль Законы һәм ТР МКның 1992 ел 18 август карары нигезендә оештырыла. Дәүләтнең тышкы икътисади сәясәтен булдыру һәм тормышка ашыру, ТРның тышкы икътисади эшчәнлеген җайга салу һәм көйләү вазифаларын башкара. Үз эченә икътисади һәм техн. экспертиза, чит ил инвестицияләре, тышкы икътисади эшчәнлек өлкәсендә мәгълүмати тәэминат, килешүләр-хокук, валюта-финанс, беркетмә, тәрҗемә, сәүдә-икътисади хезмәттәшлек һәм тарифлы булмаган

көйләү, гомуми, исәп-хисап бүлекләрен; икътисади куркынычсызлык һәм дәүләт мәнфәгатьләрен яклау секторын; киңәшчеләр төркемен, халыкара хезмәттәшлекне үстерү агентлыгын; Дәүләт теркәү палатасының респ-ка бүлеген берләштерә. ТР Президентына һәм ТР МКна буйсына. ТР Дәүләт Советының 1997 ел 19 июнь карары нигезендә гамәлдән чыгарыла, вазифалары *Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына* тапшырыла.

Министрлар: Ш.Р.Арсланов (1992–95), Р.Г.Ахунов (1995–97).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**. Казан губерна җир эшләре ком-тының 1917 ел 10 декабрь карары һәм Казан губерна җир идарәсе каршындагы игенчелек халык комиссарының 1918 ел 20 гыйнвар боерыгы нигезендә 1918 нең 6 февралендә оештырылган, 1918 нең 23 февраленнән — Казан Совет Эшче-крәстиян Респ-касының Игенчелек комис-ты, 1918 нең май–июненнән Казан губерна игенчелек комис-ты карамагындагы урман бүлегеннән башлана. Бүлек Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы Казан башкарма ком-тының 1918 ел 15 октябрь карары б-н губерна башкарма ком-ты игенчелек бүлегенең (1920дән — ТАССР Игенчелек халык комис-ты) урман бүлекчәсе итеп үзгәртеп оештырыла. РСФСР Игенчелек халык комис-тының 1921 ел 3 март карары б-н — ТАССР Игенчелек халык комис-тының Урманнар идарәсе, РСФСР ХКСның 1928 ел 24 июнь карары б-н — Татарстан урман трестының (1932 дән Татарстан урман хуҗалыгы тресты) урман бүлеге, СССР ҮБК һәм ХКСның 1936 ел 2 июль карары б-н — СССР ХКС (1946 дан МС) каршындагы Баш урманнарны саклау һәм урман утырту идарәсенең Татарстан урманнарны саклау һәм урман утырту идарәсе, СССР ЮС Президиумының 1947 ел 4 апрель Указы һәм РСФСР ЮС Президиумының 1947 ел 27 июнь Указы б-н РСФСР Урман хуҗалыгы министрлыгының Татарстан урман хуҗалыгы идарәсе (1953 тән — ТАССР А.х. министрлыгы), РСФСР МСның 1959 ел 14 ноябрь карары һәм ТССР МСның 1959 ел 15 декабрь карары б-н РСФСР МСның (1965тән — РСФСР Урман хуҗалыгы министрлыгы) Баш урман хуҗалыгы һәм урманнарны саклау идарәсенең Татарстан урман хуҗалыгы һәм урманнарны саклау идарәсе, ТАССР ЮС Президиумының 1979 ел 22 август Указы б-н ТАССР (1990 нан — ТССР, 1992 дән — ТР) Урман хуҗалыгы министрлыгы итеп үзгәртелә, ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май карары нигезендә гамәлдән чыгарыла (вазифалары *Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына* тапшырыла) һәм ТР Президентының 2006 ел 22 декабрь Указы б-н ТР У.х.м. буларак торгызыла. Урманнардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм яклау өлкәсендә идарә эшләрен тәэмин итә, 2007 дән дәүләт сәясәтен, ТРда урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә дәүләт милке б-н идарә итү һәм дәүләт ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыра. Башлангыч чорда секретариат, планлаштыру-икътисад, хезмәт һәм эш хакы, урман хуҗалыгы, урманнан файдалану, урманнарны торгызу һәм саклау, урман әзерләү һәм урман химиясе, өстәмә файдалану һәм а.х., җитештерү-техник, капиталь төзелеш, хезмәтне саклау, халык куллану товарлары, урман продукциясен һәм азык-төлек булмаган товарларны сату, финанслар, кадрлар бүлекләрен; бухгалтерияне; проект-конструкторлык, тикшеренү-норматив төркемнәрен; 2007дән — урманнардан файдалану, урманнарны торгызу, дәүләт контроле, урман фондына күзәтчелек итү һәм аны саклау, икътисад һәм дәүләт заказларын урнаштыру, финанслар, бухгалтерия исәп-хисабы һәм контроль, урман фондыннан файдаланган өчен түләүләр б-н идарә итү, адм.-хуҗалык, җитештерү-техник бүлекләрен берләштерә. 20 йөз ахырында министрлык системасына 30 урман хуҗалыгы, урман хуҗалыгы техникумы, *Түбән Кама милли паркы*, 123 урманчылык, 21 йөз башында 30 урман хуҗалыгы һ.б. учреждениеләр карый. ТР Президентына, ТР МКна һәм РФнең Федераль урман хуҗалыгы хезмәтенә (1991гә кадәр ТАССР МСна һәм РСФСР Урман хуҗалыгы министрлыгына) буйсына .

Министрлар: А.А.Гуляев (1979–84), Ә.Г.Гаянов (1984–2001), З.Н.Абдуллин (2006–09), В.А.Власов (2009–10), Н.Г Мәһдиев (2010–14) , А.Ә.Нәзиров (2014 тән). Ш.у.к. *Урман хуҗалыгы* .

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ҮСЕМЛЕКЛӘРНЕ́ САКЛА́У СТА́НЦИЯСЕ**. 1963 елда РСФСР А.х. корткычлары б-н көрәш буенча Татарстан респ-ка экспедициясе (1958 дә оештырылган) җирлегендә оештырыла. 2000 дә федераль дәүләт учреждениесе (ФДУ) «Татарстан Республикасында федераль саклау станциясе», 2007 дән «Татарстан Республикасы буенча Россия авыл хуҗалыгы үзәге» ФДУ ф-лының үсемлекләрне саклау бүлеге. Аның составына кергән бүлекчәләр: а.х. җитештерүе, фитосанитария, биофабрика б-н биотехнология, сынау лаб-яләре, сигнализация һәм фаразлаулар пунктлары б-н 11 районара терр., 32 район бүлекчәсе, Әлмәт сынау лаб-ясе; 43 муниципаль районда үсемлекләрне саклау буенча белгечләре бар. Барлык җирдән файдаланучылар б-н үсемлекләрне саклау буенча чаралар уздыруга, үсемлекләрне саклау, күчерү вакытында, үсемлекләрне саклау чараларын кулланганда технологияләрне, куркынычсызлык кагыйдәләрен саклауга дәүләт контролен тормышка ашыра; ТР терр-ясендә корткычлар, авырулар, чүп үләннәре таралуга һәм аларның үсешенә фитосанитария контроле уздыра; фәнни һәм фәнни-җитештерү оешмалары б-н үсемлекләрне саклау буенча заманча технологияләр, чаралар һәм алымнар кертү өлкәсендә хезмәттәшлек итә, а.х. культураларының төп корткычлары һәм авыруларына санитария фаразларын төзи, күрсәтмәләр бирә, җирле файдалы энтомофауналарның барлыгын-юклыгын билгели, аларны саклау һәм этномофагларның санын арттыру буенча чаралар тәкъдим итә. Биофабрика үсемлекләрне биол. саклау чараларын (биофунгицидлар, биоинсектицидлар һәм файдалы бөҗәкләр): ризоплан, бактероденцид, битоксибацилин, бацикол, микроашламалар, бинарам, триходермин, трихограмма, златоглазка, энкарзия һ.б. җитештерә. Лаб-яләр азык продуктларындагы, чималдагы һәм әйләнә-тирә мохит объектларындагы пестицидларны, авыр металлар тозы, нитратлар, микотоксин, нитрозалин, бензапиреннарны анализлый, яңа килгән һәм срогы чыккан пестицидларны, орлыклык материалларны агулау сыйфатын, азык продуктларының, бөртекле, бөртекле-кузаклы, май, техник, яшелчә, җиләк-җимеш һәм бакча культураларының сертификатын тикшерә. Үсемлекләрне саклау чаралары куллану респ-ка буенча ел саен арта. 2014 тә чүп үләннәре б-н көрәш буенча эш 1764,9 мең *га* мәйданда, корткычлар б-н — 818,6 мең *га* мәйданда, авырулар б-н 338,8 мең *га* мәйданда башкарыла, ш.у. 428,1 мең *т* орлыклык материал инкрустацияләнә. Татарстанда үсемлекләрне саклау хезмәте җитәкчеләре: В.И.Алексеев (1963–65), С.В.Муллин (1966–67), Л.П.Демаков (1968–69), Л.Н.Веткин (1970–77), Б.М.Әхмәдов (1978–83), Ф.Х.Галәветдинов (1984–98), Н.М.Денисенко (1999–2000); А.Х.Садриев (2001–07), Т.Г.Һадиев (2008–14), 2014 тән В.В.Минһаҗев. Ш.у.к. *Үсемлекләрне саклау*.

*Әд.:* Защита растений в Татарской АССР. К., 1980; Защита растений и охрана природы в Татарстане. К., 2000. Вып. 6; Фитосанитарный прогноз основных вредителей и болезней сельскохозяйственных культур на 2008 год и система мероприятий по борьбе с ними в Республике Татарстан. К., 2008.

*И.Н.Афанасьев.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ФӘ́ННӘ́Р АКАДЕ́МИЯСЕ́** (ТР ФА), респ-каның фән, техника һәм иҗтимагый үсешенә күренекле өлеш керткән галимнәрнең һәм мәдәният эшлеклеләренең иң югары фәнни оешмасы. Ул үзенең эшчәнлеген ТР Президенты М.Ш.Шәймиевнең «Татарстан Республикасының Фәннәр академиясен оештыру турында» 1991 ел 30 сентябрь Указы нигезендә «...республикада фундаменталь фәннәрнең югары дәрәҗәдәге үсешен тәэмин итү, матди һәм рухи мәдәниятнең актуаль мәсьәләләрен хәл итүдә респ-каның акад., тармак институтларында һәм югары уку йортларында фәнни-тикшеренү эшләрен координацияләүдә аларның ролен көчәйтү максатларында» 1992 нең 24 гыйнварында башлый. Илебез тормышында 1990 еллардагы кискен борылыш чорында ТР ФА респ-каның фәнни мәктәпләрен һәм әйдәп баручы галимнәрен саклауга, туплауга һәм үстерүгә, фәнни-техник эшчәнлек өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен билгеләүгә зур өлеш кертә. Аның башлангычында Казанда Табигать системалары экологиясе ин-ты (1993, хәзер *Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институты*), Татар энциклопедиясе ин-ты (1994, хәзер *Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты*), *Тарих институ-*

*ты* (1997) оештырыла. Фәнни тикшеренүләрнең нәтиҗәлелеген үстерү максатында академия *Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк институты, Бөтенроссия углеводород чималы институты, Татарстан нефть фәнни-тикшеренү һәм проект институты (ТатНИПИнефть)* һ.б. эшчәнлегенә фәнни-методик җитәкчелек итә. Бу елларда ТР ФА президиумы һәм аның бүлекләре каршында табигыять һәм иҗтимагый фәннәрнең аеруча мөһим мәсьәләләре буенча ТР ФА әгъзаларыннан тыш 400 дән артык фән д-рын һәм 500 дән артык фән канд-тын берләштергән 40 тан артык гыйльми совет оештырыла.

ТР МКның 2012 ел 2 октябрь 818 нче карары нигезендә хәзерге академиянең статусы дәүләт фәнни бюджет учреждениесе («ТР Фәннәр академиясе» ДФБУ; ТР ФА), үз составында танылган галимнәрне, мәдәният эшлеклеләрен, ш.у. аның аерымланган структур подразделениеләрендәге фәнни хезмәткәрләрне берләштерүче коммерциячел булмаган оешма буларак тәгаенләнә. Хәзер ТР ФАн оештыручы буларак Татарстан Респ-касы сыйфатлана, оештыручының вазифалары һәм вәкаләтләре ТР МК Аппаратына тапшырылган.

ТР ФА үзенең көндәлек эшчәнлегендә РФ, ТР законнарына һәм үз Уставына таяна. Академиянең идарә органнары: гомуми җыелыш — аның иң югары органы, ТР ФА президиумы, ТР ФА президенты. ТР ФАнең гомуми җыелышы кимендә елга бер тапкыр чакырыла; җыелышта президентның ел дәвамында башкарылган эше турындагы хисабы тыңлана, академиянең үсеш стратегиясе билгеләнә, аның Уставы кабул ителә һәм раслауга ТР МКна җибәрелә.



ТР Фәннәр академиясе.

ТР ФА президиумы — даими рәвештә эшләүче коллегиаль идарә органы, эшен академия президенты рәислегендә башкара, аның составының кимендә 51% академия әгъзаларының гомуми җыелышында 5 елга сайлана, ТР ФА президиумының калган әгъзалары дәүләт хакимияте, югары уку йортлары, фәнни-тикшеренү институтлары һәм эшмәкәрлек вәкилләре арасыннан ТР Президенты тарафыннан раслана; айлык вазифаи хезмәт хакы билгеләнә. ТР ФА президиумы составына ш.у. Вице-президентлар, баш гыйльми секретарь, академия бүлекләренең акад.-секретарьлары керә.

ТР ФА президенты академиянең гомуми җыелышында аның хакыйкый әгъзалары арасыннан 5 елга сайлана һәм үз вазифасында ТР Президенты тарафыннан раслана. Академиядә 40 хакыйкый әгъза, 80 мөхбир әгъза, 28 шәрәфле әгъза һәм чит илләрдән 14 әгъза исәпләнә. ТР ФАнең хакыйкый әгъзалары һәм мөхбир әгъзалары бюджеттан гомерлек стипендия алалар. Алар составында белемнәрнең тиешле өлкәләре һәм фән юнәлешләре буенча 7 бүлек — гуманитар фәннәр; социаль-икътисади фәннәр, мед. һәм биол. фәннәре; а.х. фәннәре; матем., механика һәм машина төзелеше; физика, энергетика һәм Җир турындагы фәннәр; химия һәм химик технологияләр бүлекләре оештырыла. Академиянең 2 фәнни советы — табигыять-техник һәм социаль-гуманитар советлары эшли. Алар ТР Хөкүмәте карары буенча респ-каның икътисади һәм социаль үсеше программаларына экспертиза уздыралар, фән һәм мәгариф өлкәсендә закон актларын эшләүдә катнашалар.

Академия аркылы респ-ка, иң элек фәнни проектлар, хуҗалык килешүле эшләр башкару мөмкинлеге тудыру юлы б-н, гомумроссия грантлар конкурслары оештыру аша (РГФФ, РФТФ), фәнни мәктәпләргә финанс ярдәме күрсәтә, аларның фәнни-тикшеренү эшчәнлеген координацияли.

Нефтьче галимнәр нефть эзләү, катламнардан нефть чыгару темпларын күтәрү һәм аларның нефть бирүчәнлеген арттыру буенча яңа технологияләр эшлиләр һәм гамәлгә



ТР ФАнең еллык җыелышында катнашучылар. 1994, февраль.

кертәләр; яңа кадрлар әзерләүдә катнашалар; традицион булмаган коллекторлардагы нефть (академиклар Р.Х.Мөслимов, Р.Р.Ибәтуллин), традицион булмаган битумлы нефть (хакыйкый әгъза Р.С.Хисамов) запасларын геол. өйрәнү һәм эшкәртү буенча яңа карашлар булдыру эшләре башкарыла; чи нефтьне һәм нефть продуктларын күкертле пычранулардан чистарту өчен Россиядә һәм чит илләрдә күпсанлы патентлар б-н яклаган технологияләр һәм җайланма эшләнә, гамәлгә кертелә (акад. Ә.М.Мазһаров). ТР ФА галимнәренең технологияләрен гамәлгә кертүдән экономия эффекты миллиардларча сумнар тәшкил итә. Физика галимнәре (академиклар И.Б.Хәйбуллин, М.Х.Сәлахов, мөхбир әгъза Л.Р.Таһиров) тарафыннан микро- һәм оптик электроника, исәпләү техникасы һәм голография өчен уникаль сыйфатлы яңа перспективалы ярымүткәргечле, оптик, магнитлы материаллар алу технологияләре булдырыла. Онкологик һ.б. авыруларны иртә диагнозлау өчен оригиналь түбән кырлы җайланма эшләнә һәм ТМР-томография алымы камилләштерелә (акад. К.М.Салихов, хакыйкый әгъза Ә.В.Ильясов).

Машиналар төзелеше өлкәсендә ТР ФА галимнәре «КАМАЗ» ААҖ, «Россия вертолётлары» ААҖ һ.б. белгечләре б-н тыгыз хезмәтәшлек итәләр, ягулыкның альтернатив төрләрендә эшләүче һәм перспектив экологик таләпләрне үтәү потенциалына ия 300–400 ат көчле КАМАЗ двигательләрен эшләүдә катнашалар (җитәкче — акад. Ю.Ф.Гортышев); мөхбир әгъза С.А.Михайлов җитәкчелегендә композит планерның, очучысыз ерак араларга очучы аппаратның тәҗрибә үрнәкләре эшләнә һәм җитештерелә, акад. И.М.Закиров җитәкчелегендә полимер-композиция материалларыннан 4 урынлы самолёт-технологияләр демонстраторы җирлегендә гомуми максаттагы авиация (ГМА) самолётлары модельләре сафындагы югары аэродинамика сыйфатлы планер агрегатлары (канат, стабилизатор) ясау өчен фәнни нигезләр һәм проект эшләнмәләре булдырыла.

Аграрий галимнәре тарафыннан а.х. фәннәрендә инновацион технологияләргә — а.х. биотехнологиясе үсешенә, мәгълүмати һәм нанотехнологияләргә, а.х.нда терлекчелектә һәм үсемлекчелектә куллану өчен яңа буын препаратлар җитештерүгә аерым игътибар юнәлтелә. Бөртекле, техник һәм азык культуралары уңышының 7–12% ка артуын, көчәя барган техноген басым шартларында агроэкология халәтен күпкә яхшыртуны, терлекләрдәге һәм үсемлекләрдәге йогышлы булмаган авырулар нәтиҗәсендәге югалтуларны киметүне тәэмин итүче технол. алымнар эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Импортны алыштыручы «Рекодез» дезинфекция чарасы (акад. Г.З.Равилов фәнни мәктәбе) эчәргә яраклы су б-н тәэмин итү, сәнәгать канализациясе системаларын, технол. җиһазларны чистарту һәм дезинфекцияләү, үткәргеч торбаларда биол. элпәдән арыну өчен эшләнә. Терәк-хәрәкәт аппаратындагы тайпылышларны һәм зарарлануларны дәвалау өчен мед. галимнәре (мөхбир әгъза Х.З.Гаффаров, мед. фән. д-ры А.З.Гиммельфарб, 1 нче Респ-ка клиник хастаханәсе каршындагы «Травматология һәм ортопедия» фәнни-тикшеренү үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Я.Х.Ибраһимов һ.б.) тарафыннан 100 дән артык дәвалау җайланмасы һәм ысуллары булдырыла, патентлар б-н яклана. Эре буыннарны эндопротезлау өлкәсендә алар тарафыннан 28 конструкция эшләнә һәм аларга ш.у. патентлар алына. Техник чишелеш дәрәҗәсе буенча әлеге җайланмаларга дөньяда тиңнәр юк, аларның күбесе гаять оригиналь идеяләргә нигезләнә.

Астрофизика галимнәре (акад. Н.А.Сәхибуллин) Мәскәү (ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы, РФА академигы Р.Г.Сюняев һ.б.), Ленинград оптика-механика берләшмәсе һәм Төркия тикшеренүчеләре б-н берлектә, 1,5 *м* диаметрлы РТТ 150 телескобын эшләп, Анталья ш. (Төркия) тирәсендә урнаштыралар; ТР ФАнең «Астрофизика» үзәге галимнәре эре халыкара космик проектларда катнашалар. Европаның күп кенә илләре һәм АКШ катнашындагы INTEGRAL кысаларында алар тарафыннан берничә яңа галактика ачыла, хәвефле астероидларны эзләү һәм аларны күзәтү буенча эш башкарыла.

ТР ФА составында аның төп аерымланган структур оешмалары булган 6 институт һәм 2 үзәк эшли: Г.Ибраһимов исем. *Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*, Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү ин-ты, А.Х.Халиков исем. Археология ин-ты, Гамәли семиотика ин-ты, Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары ин-ты, Перспектив гамәли тикшеренүләр ин-ты, Гаилә һәм демография үзәге, Исламны өйрәнүтикшеренүләр үзәге. Академиядә эшләүчеләрнең гомуми саны — 412 кеше, шулардан фәнни хезмәткәрләр — 305 кеше (74%), ш.и. 46 фән д-ры (15%) һәм 138 фән канд. (45%).

Соңгы елларда гуманитар фәннәр өлкәсендә зур гомумфәнни һәм социаль-мәдәни әһәмияткә ия программалар буенча тикшеренүләр уздырыла. Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты тарафыннан күптомлы хезмәтләр — өч томлы «Татар лексикологиясе», 2015, 1 т.), өч томлы «Татар грамматикасы», 2015, 1 т.), «Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр — XX гасыр башы)», 2015, 1 т.), сигез томлы «Татар әдәбияты тарихы», 2014–15, 1–3 т.), рус телендә унбиш томлы «Татар халык иҗаты» («Татарское народное творчество», 2008–15, 1–5 т.) әзерләнә һәм басыла, Г.Исхакыйның «Әсәрләр», 1998–2014, 1–15 т.) һәм Г.Тукайның «Әсәрләр», 2011–16, 1–6 т.) акад. басмаларын нәшер итү тәгәлләнә, 2016 да «Габдулла Тукай: Энциклопедия» китабы дөнья күрә.

ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү ин-ты тарафыннан тарихта беренче «Татар энциклопедиясе»н эшләү тәгәлләнә, аның рус телендәге барлык алты томы (2002–14), ш.у. татар телендәге дүрт томы (2008–14) басылып чыга, 5 һәм 6 нчы томнарны матбугатка әзерләү дәвам итә; «Татарстан: Иллюстрацияле энциклопедия» («Татарстан: Иллюстрированная энциклопедия», 2013; 2 нче басма, 2015), ТАССРның 90 еллыгына иллюстрацияле «Татарстан: табигать, тарих, икътисад, мәдәният, фән» («Татарстан: природа, история, экономика, культура, наука», 2010; 2 нче басма 2015), «Татарстан Республикасының юкка чыккан авыллары» («Исчезнувшие населённые пункты Республики Татарстан, 2016), «Казакъстан татарлары» («Татары Казахстана», 2016) энциклопедик белешмәлекләре нәшер ителә; «Татарстан Республикасының табигате һәм табигый ресурслары» («Природа и природные ресурсы Республики Татарстан») энциклопедиясе басмага әзерләнә. Институтта ш.у. өч томлы «Татарстан Республикасының торак пунктлары» («Населённые пункты Республики Татарстан») энциклопедиясе, «Россия Федерациясендә татарлар тупланып яшәгән төбәкләр» («Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации») фәнни-белешмәлек басмалары һ.б. эшләнә.

А.Х.Халиков исем. Археология ин-ты тарафыннан Татарстанның этник тарихын һәм мәдәниятен комплекслы фәнни реконструкцияләү буенча эшчәнлек алып барыла. Коллектив борынгы Болгар шәһәрен ЮНЕСКО бөтендөнья мирасы исемлегенә кертүгә әзерләнү (2014), Болгар шәһәрендә «Болгар цивилизациясе» музеен, Зөя шәһәрендә «Татар бистәсе» музеен оештыру юнәлешендә зур эшләр башкара, ТРның Археол. музеен ачуга әзерлек алып барыла. Археол. ин-тының тикшеренүләре Идел-Кама төбәгенең һәм Евразия далаларының борынгы тарихын торгызуда төп чыганак җирлеге булып тора. Фәнни проектларның бер өлеше «Татарстаннан читтә яшәүче татарлар» дип аталган гомуми исем астында берләштерелә. ТРда, РФдә һәм чит илләрдә (Болгария, Румыния, Казакъстан, Монголия һ.б.) татарлар тупланып яшәгән җирләргә экспедицияләр оештырыла. Әлеге тикшеренүләр татарларның ерак үткәндәге тормышы һәм көнкүреше, мәдәнияте, шәһәр төзелеше традицияләре турында яңа мәгълүматлар алу мөмкинлеге тудыра.

Академиядә табигыять-техник юнәлешләр дә үсеш кичерә. Экология һәм казылма байлыклардан файдалану проблемалары ин-ты тарафыннан сәнәгать шәһәрләре атм. һавасы сыйфаты формалашуның антропоген факторларын анализлау нәтиҗәләре буенча зарарлы матдәләрнең атмосферага чыгу параметрлары мәгълүматлары базалары формалаштырыла, алар табигатьне саклау чараларын дәлилләгәндә, шәһәр төзелешенә караган карарлар кабул иткәндә файдаланыла. Казандагы һәм шәһәр яны зонасындагы хуҗалык һәм спорт үсеше өчен әһәмияткә ия төрле типтагы сулыкларның экологик халәтен өйрәнү буенча мөһим тикшеренүләр алып барыла. Кече һәм урта аграр эшмәкәрлек пр-тиеләрен диагнозлау халыкны экологик яктан куркынычсыз продукция б-н тәэмин итүдә респ-ка а.х. җитештерүчеләренең потенциалын бәяләү мөмкинлеге бирә. Респ-каның көньяк-көнчыгыш терр-яләрендә туфрак яңартылып эшкәртелгәннән соң, аның составындагы нефть һәм нефть продуктлары калдыкларының рөхсәт ителгән нормативлары булдырыла.

Перспектив тикшеренүләр ин-тында икътисадның реаль секторында куллану өчен «болытлы» модельләштерү сервислары эшләнә. Транспорт логистика системаларын имитацион модельләштерү өлкәсендә билгеле бер нәтиҗәләргә ирешелә. Ин-т нефть-газ секторының фәнни-техник мәсьәләләрен хәл итүгә кушыла. «Гамәли семиотика» ин-ты тарафыннан татар теленең сөйләм технологияләре — татар теленең «Туган тел» электрон корпусы, «Tatar-Online» мультимедия электрон дәреслекләре, рус-татар машина тәрҗемәсе системасы булдырыла, программалы продуктларның локальләштерелгән версияләре әзерләнә.

Академиянең «Фән» нәшрияты бар, ул рус һәм татар телләрендә чыгучы «Фәнни Татарстан» — «Научный Татарстан» ж-лларын оештыручы булып тора. Кайбер институтларда махсус фәнни журналлар нәшер ителә («Поволжская археология» һ.б.).

ТР ФА ТРның Фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт бүләкләре ком-ты вәкаләтләренә ия; аның тарафыннан ТР ФАнең «Фәнни казанышлар өчен» Алтын һәм Көмеш медальләре, 9 исемле бүләк: Ш.Мәрҗани исем. (гуманитар фәннәр), Г.Ибраһимов исем. (татар тел белеме һәм әдәбият белеме өлкәсендә), Х.М.Мөштәри исем. (матем., механика һәм техник фәннәр), Ә.Г.Терегулов исем. (мед. һәм сәламәтлек саклау), А.Д.Адо исем. (аллергология, иммунология һәм гомуми патология), В.А.Энгельгардт исем. (биол.), К.Г.Боль исем. (вет.), В.П.Мосолов исем. (а.х.) бүләкләр булдырылган, академиягә ТРның фән һәм техника өлкәсендәге — физика буенча Е.К.Завойский исем., химия буенча А.Е. һәм Б.А.Арбузовлар исем., инженерлык фәннәре буенча А.Н.Туполев исем., инженерлык фәннәре буенча яшь галимнәр өчен В.Е.Алемасов исем. халыкара һәм дәүләт бүләкләре ком-тларының эшчәнлекләрен оештыру мәсьәләләре ягыннан тәэмин итү йөкләнгән.

Халыкара фәнни бергәлек б-н бәйләнешләр системасы булдырылган. ТР ФА галимнәре РФнең 40 тан артык төбәгенең фәнни учреждениеләре һәм чит илләрдәге фәнни оешмалар б-н хезмәттәшлек турында килешүләр нигезендә элемтәдә тора, аларның күбесе б-н элегрәк имзаланган хезмәттәшлек программалары буенча уртак чаралар гамәлгә ашырыла.

ТР ФА президентлары: М.Х.Хәсәнов (1992–2006), Ә.М.Мазһаров (2006–14), М.Х.Сәлахов (2014 тән).

*Әд.:* Академия наук Татарстана. К., 1994; Академия наук Республики Татарстан. К., 2016.

*Д.Ф.Заһидуллина, Г.С.Сабирҗанов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ФӘННӘ́Р АКАДЕ́МИЯСЕ БҮЛӘКЛӘРЕ́**. Фәнни хезмәтләр, ачышлар һәм уйлап табулар өчен билгеләнә. ТР ФА б.: *Завойский Е.К. исемендәге халыкара бүләк* (1991), *Халыкара Арбузов бүләге* (1997), Туполев А.Н. исем. халыкара бүләк (2014), ш.у. Шиһабетдин Мәрҗани исем. бүләк — гуманитар фәннәр өлкәсендәге хезмәтләр өчен бүләкләү максатыннан ТР ФА Президиумының 1993 ел 17июнь карары б-н гамәлгә кертелә (2016 елның 1 гыйнварына — 7 лауреат); Гыйлем Камай исем. бүләк — химия өлкәсендәге хезмәтләр өчен бүләкләү максатыннан ТР ФА Президиумының карары б-н гамәлгә кертелә (7 лауреат); Х.Мөштәри исем. бүләк — математика, механика һәм техник фәннәр өлкәсендәге хезмәтләр өчен бүләкләү максатыннан ТР ФА Президиумының 1993 ел 17 июнь карары б-н гамәлгә кертелә (18 лауреат); В.Энгельгардт исем. бүләк — биол. өлкәсендәге хезмәтләр өчен бүләкләү максатыннан ТР ФА Президиумының 1993 ел 17 июнь карары б-н гамәлгә кертелә (15 лауреат); Ә.Терегулов исем. бүләк — медицина һәм сәламәтлек саклау өлкәсендәге хезмәтләр өчен бүләкләү максатыннан ТР ФА Президиумының 1993 ел 17 июнь карары б-н гамәлгә кертелә (8 лауреат); К.Боль исем. бүләк — вет. өлкәсендәге хезмәтләр өчен бүләкләү максатыннан ТР ФА Президиумының 2000 ел 11 май карары б-н гамәлгә кертелә (11 лауреат); В.Мосолов исем. бүләк — а.х. фәннәре өлкәсендәге хезмәтләр өчен бүләкләү максатыннан ТР ФА Президиумының 2000 ел 11 май карары б-н гамәлгә кертелә (8 лауреат); А.Адо исем. бүләк — аллергология, иммунология һәм гомуми патология өлкәсендәге хезмәтләр өчен бүләкләү максатыннан ТР МКның 2001 ел 25 июнь карары б-н гамәлгә кертелә (9 лауреат); В.Попов исем. бүләк — табигатьтән рациональ файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге хезмәтләр өчен бүләкләү максатыннан ТР ФА Президиумының 2003 ел 9 октябрь карары б-н гамәлгә кертелә (9 лауреат); Г.Ибраһимов исем. бүләк — татар теле һәм әдәбият белеме өлкәсендәге хезмәтләр өчен бүләкләү максатыннан ТР ФА Президиумының 2013 ел 21 февраль карары б-н гамәлгә кертелә (1 лауреат), В.Е.Алемасов исем. ТР Дәүләт бүләге – яшь галимнәрнең инженерлык фәннәре өлкәсендәге инновацион эшчәнлекләре өчен ТР Президентының 2014 ел 24 сентябрь Указы б-н гамәлгә кертелә (6 лауреат).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ФӘННӘ́Р АКАДЕ́МИЯСЕНЕҢ ФӘННИ́ КИТАПХАНӘСЕ́**. 1936 елның 11 июнендә нигезләнә; ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты карамагында, аннан соң Респ-ка кадрлар әзерләү һәм белем күтәрү үзәге каршында була. ТАССР МКның 1991 нең 6 ноябрь карары нигезендә ТР ФАнә тапшырыла. Китап фонды шуны исәпкә алып туплана. Китапханә Сәяси мәгариф йорты һәм халык ун-тларында уздырыла торган лекцияләр, семинарлар, докладлар әзерләүдә ярдәм күрсәтү максатыннан оештырыла. Китапханә фондында совет чоры басмалары гына түгел, рев-циягә кадәрге чыганаклар, ш.и. Казан ун-ты профессоры Д.И.Мейерның «Хокук җыентыгы» («Юридический сборник», 1855), М.Богдановичның «Казан камалышының инженерия-тарихи тасвирламасы...» («Инженерно-исторический очерк осады Казани...», СПб., 1898), К.Ф.Фуксның «Казан шәһәренең кыскача тарихы» («Краткая история города Казани», 1905) хезмәтләре һ.б. бар. ТР ФА составына кертелү вакытыннан башлап, китапханә фонды фән һәм техниканың барлык тармакларына караган басмалар, ш.и. авторлар тапшырган китаплар (үз хезмәтләрен академиклар М.З.Зәкиев, Ә.Г.Кәримуллин, М.К.Михайлов, Р.С.Сәйфуллин, К.М.Салихов һ.б. бүләк итә), «Мәгариф», «Фән» нәшриятлары, Татар энциклопедиясе ин-тыннан мәҗбүри рәвештә тапшырыла торган экземплярлар, китапханәләрнең алмаш фонды; коммерцияле булмаган «Пушкин китапханәсе» («Пушкинская библиотека») китап бастыруга ярдәм фонды һ.б. хисабына туплана. 2015 тә китап фонды 211657 берәмлек тәшкил итә, аларның 3075 е — вакытлы матбугат чаралары. Китапханәдә 1990–2016 елларда нәшер ителгән журнал төпләмәләре саклана. Һәр елны 800 гә якын басма кабул ителә. Укучылар арасында — фәнни хезмәткәрләр, укытучылар, дәүләт эшлекләре, аспирантлар, студентлар бар. Электрон каталогында 2 мәгълүмат базасы: «Вакытлы матбугат», «Китаплар» (барысы 30 меңнән артык документ).

Мөдирләре: М.А.Колтырева, Г.В.Рәхимҗанова (1965–78), Н.А.Литвинова (1978–88), Т.К.Вәлиәхмәтова (1989–2016), Д.Р.Галиуллина (2016 дан).

*Т.К.Вәлиәхмәтова.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ФИНА́НС МИНИ́СТРЛЫГЫ**. Тарихы Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна советының 1917 ел 16 һәм 19 ноябрь карарлары нигезендә губерна советының финанс комиссиясе оештырылудан башлана. Комиссия Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна советы гомуми җыелышының 1918 ел 26 февраль карары б-н — Казан Совет Эшче-Крәстиян Респ-касының Финанс комис-ты, Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна башкарма ком-тының 1918 ел 16 май һәм Казан губернасы ХКСның 1918 ел 3 июнь карарлары б-н — Казан губернасы Финанс комис-ты, Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы Казан губерна башкарма ком-тының 1918 ел 22 июнь һәм 15 октябрь карарлары һәм РСФСР ХКСның 1918 ел 31 октябрь Декреты б-н — губерна башкарма ком-тының финанс бүлеге, БҮБК һәм РСФСР ХКСның 1920 ел 27 май Декреты һәм ТАССР ҮБКның 1920 ел 28 сентябрь карары б-н ТАССР Финанс халык комис-ты итеп үзгәртелә. Халык комис-ты урыннарда финанс органнары оештыру; респ-ка ведомстволары тарафыннан тәкъдим ителгән финанс сметаларын төзү, карау һәм тикшерүгә күзәтчелек итү; респ-ка бюджеты проектларын һәм җирле бюджет җыелмасын төзү; кредитлар тарату, кичектерү һәм исәбен алып бару; салым сәясәте үткәрү; респ-ка карамагындагы пр-тие һәм учреждениеләрнең хисапларын һәм балансларын тикшерү; җирле әһәмияткә ия кредит оешмаларын күзәтчелек астына алу һ.б. б-н шөгыльләнә. 1920 елларда аның составына эшләр башкару, бюджет, салым, дәүләт керемнәре, салымнардан тыш керемнәр, валюта, дәүләт финанс контроле идарәләре; финанс инспекциясе; хисап-стат. часте; кадрлар секторы; 1930 еллардан бюджет,

дәүләт керемнәре, салымнар, халык хуҗалыгын финанслау, штатлар, финанс-хуҗалык бүлекләре; СССР Финанс халык комис-тының ТАССР буенча контроль-хисап идарәсенең өлкән контролёр-ревизоры аппараты керә. ТАССР ҮБКна (1938 гә кадәр), ТАССР ХКСна һәм шул ук исемдәге РСФСР Халык комис-тына буйсына.

ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы нигезендә ТАССР Финанс халык комис-ты ТАССР (1990 нан — ТССР, 1992 дән — ТР) Финанс министрлыгы итеп үзгәртелә. Бөек Ватан сугышыннан соң Министрлыкның төп бурычларын акчаларны туплау һәм аларны халык хуҗалыгын финанслауга юнәлдерү, респ-ка учреждениеләре һәм пр-тиеләре тарафыннан финанс дисциплинасы саклануны контрольдә тоту тәшкил итә. Хәзерге вакытта ул бердәм дәүләт финанс сәясәтен үткәрә һәм ТРда финанс эшләрен оештыруга гомуми җитәкчелекне тормышка ашыра. Икътисад; икътисади анализ; бюджет; төбәкләр бюджеты б-н үзара мөнәсәбәт; гомуми; адм.-хуҗалык; халык хуҗалыгын финанслау; а.х. һәм азык-төлек тармагын финанслау; сәламәтлек саклау, социаль сәясәт һәм тәртип саклау органнарын финанслау; мәгариф һәм мәдәниятне финанслау; торак-коммуналь хуҗалык тармакларын финанслау; идарә аппаратын финанслау; бюджет сәясәте һәм финанс базарлары; мәгълүматлаштыру; исәп-хисап һәм отчёт; кадрлар; хокук бүлекләрен үз эченә ала. Министрлык карамагында казначейство департаменты һәм аның терр. бүлекчәләре, ТРның дәүләт ихтыяҗларын продукция б-н тәэмин итүче «Татгоспоставки» дәүләт учреждениесе; шәһәр һәм районнар буенча 42 финанс идарәсе һәм бүлеге бар. ТР Президентына, ТР МКна (1991 гә кадәр — ТАССР МС) һәм РФнең шул ук исемдәге министрлыгына буйсына.

Халык комиссарлары һәм министрлар: А.С.Гордеев (1920 – сент., 1924), И.Р.Бурнашев (сент.–нояб., 1924), О.В.Бекбулатов (дек., 1924–гыйн., 1925), А.В.Недачин (гыйн., 1925–1926), Н.Д.Кочкарин (1926–27), А.А.Терский (1927 – гыйн., 1930), Х.Г.Тарпищев (гыйн.–июль, 1930), К.Х.Мәһдиев (июль, 1930–1937), С.М.Шәрәфиев (1937–42, 1951–57), Г.Х.Хәйруллин (1942–43), М.Җ.Азизов (1943–50), Х.Ә.Әюпов (1950–51, 1957–69), Ш.Ә.Мостаев (1969–84), Х.С.Хәбибуллин (1984–88), Р.Г.Мингазов (1988–90), Д.Н.Нагуманов (1990–96), Р.Н.Миңнеханов (1996–98), Р.Р.Мусин (1998–2002), Р.Р.Гайзатуллин (2002 дән).

*Е.Б.Долгов.*

**«ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ХАЛЫ́К МӘГАРИФЕ́ ТУРЫНДА́ КҮРСӘТМӘ́»**, Бөтенроссия ҮБК декреты, БҮБК һәм ХКСның «Автономияле Татар Совет Социалистик Республикасы турында» Декреты б-н бер үк вакытта халыкка игълан ителә. 1920 елның 27 маенда Бөтенроссия ҮБК рәисе М.И.Калинин һәм Бөтенроссия ҮБК секретаре А.А.Енукидзе кул куя. ТАССРның Вакытлы революцион ком-тка (Халык комиссарлары советына) юлланган законнар чыгару актында ТАССР Мәгариф халык комис-тында азчылык милләтләр бүлеген булдырырга (бу бүлекнең җитәкчесе РСФСР Мәгариф халык комис-ты килешүе нигезендә билгеләнә) һәм татарлардан кала азчылык милләтләр саны 10% тан ким булмаган өяз, кантоннарның мәгариф оешмаларында шундый ук бүлекчәләр ачарга тәкъдим ителә. РСФСР Мәгариф халык комис-ты тарафыннан ТАССР Мәгариф халык комис-тына йөкләнгән элеге «гадәттән тыш бурычларның» үтәлүе мәҗбүри булуы әйтелә. Шул сәбәпле Һөнәри-техник белем бирү баш ком-ты, Бөтенроссия наданлыкны бетерү гадәттән тыш комиссиясенең һәм охшаш учреждениеләрнең оештыру күрсәтмәләре, уку планнары һәм программалары ТАССР терр-ясендә дә гамәлдә була. Декретта элеккечә РСФСР Мәгариф халык комис-ты карамагында булган һәм аның сметалары буенча финансланган Казан ун-ты статусы турында аерым искәртелә. Татарстан Респ-касы хакимияте ун-тның уку-укыту һәм адм. эшчәнлеген ТАССР Мәгариф халык комис-ты вәкиле аша контрольдә тота, ул вәкил ун-тның идарәче коллективларының барлык утырышларында (совет, президиум, идарә һ.б.ш.) булырга һәм тавыш бирергә хокуклы була. РСФСР Мәгариф халык комис-тына киләчәктә ун-тта төбәк тарихы, археологиясе һәм этнографиясе, җирле халыклар һәм шәрекъ телләрен укыту каф. б-н төбәк ф-ты ачу эшенә тотынырга тәкъдим ителә. Җирле предметларны нинди телдә укыту мәсьәләсен РСФСР һәм ТАССР Мәгариф халык комис-ты килешүе буенча хәл итү планлаштырыла.

Чыг.: Образование Татарской АССР: Сб. док. и материалов. К., 1960.

*Әд.:* Т а г и р о в И.Р. История национальной государственности татарского народа и Татарстана. К., 2008. *Р.В.Шәйдуллин.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ХАЛЫККА́ КӨ́НКҮРЕШ ХЕЗМӘТЕ́ КҮРСӘТҮ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**. ТАССР МСның 1960 ел 16 ноябрь күрсәтмәсе нигезендә ТАССР Җирле сәнәгать министрлыгы каршындагы (1962 дән — ТАССР МС каршындагы) халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү идарәсе буларак оештырыла, ТАССР ЮС Президиумының 1966 ел 8 гыйнвар карары һәм РСФСР ЮС Президиумының 1966 ел 12 гыйнвар Указы нигезендә ТАССР (1990 нан — ТССР, 1992 дән — ТР) Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү министрлыгы итеп үзгәртелә. Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәрүгә җитәкчелек итә. Секретариат, бухгалтерия, җитештерү-техник, планлаштыру-икътисад, финанс, торак һәм йорт җиһазы ремонтлау бүлекләрен берләштерә. Министрлык карамагына халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүнең район идарәләре, «Татмебельбыт», «Татшвейбыт», «Татфото», «Татремобувьбыт», «Татхимчистка», «Татбытпрокат», «Татбытреклама», «Таттрикотажбыт», «Таттелерадиобыттехника», «Казгорпарикмахер», «Зима», «Казгорбыткомбинат» җитештерү оешмалары, ритуаль хезмәт комб-ты, уку комб-ты керә. ТР Президентына, ТР МКна (1991 гә кадәр — ТАССР МСна һәм РСФСРның шул тармак министрлыгына) буйсына. ТР Дәүләт Советының 1995 ел 22 июнь карары нигезендә гамәлдән чыгарыла, вазифалары ТР Сәүдә һәм кулланучыларга ярдәм министрлыгына тапшырыла.

Министрлар: В.П.Фадеев (1966–84), Р.Р.Гыйләҗев (1984–85), Е.Б.Богачёв (1985–93), Л.Н.Малышев (1993–95). Ш.у.к. *Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү.*

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ХЕЗМӘ́Т, МӘШГУЛЬЛЕ́К ҺӘМ СОЦИА́ЛЬ ЯКЛА́У МИНИ́СТРЛЫГЫ**. ТР Президентының 2007 ел 14 июнь Указы һәм ТР Дәүләт Советының 2007 ел 14 июнь карары нигезендә *Татарстан Республикасы Социаль яклау министрлыгы* һәм *Татарстан Республикасы Хезмәт һәм мәшгульлек министрлыгы* җирлегендә оештырыла. Хезмәт, мәшгульлек һәм халыкны социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәрүне тәэмин итә. Эшләр башкару; финанс; хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау идарәләрен; тармак анализы, фаразлау һәм программалаштыру; җәмгатьчелек б-н элемтә; мәгълүмат-аналитика; ведомствога караган учреждениеләрне координацияләү; мәшгульлек һәм хезмәт базары программалары; һөнәри белем бирү, һөнәр сайларга булышу һәм психол. ярдәм; эшкә урнаштыру һәм махсус программалар; хезмәт мөнәсәбәтләрен көйләү; хезмәтне саклау; хезмәт шартларының дәүләт экспертизасы; эш урыннары аттестациясе; социаль хезмәт күрсәтү методологиясе; социаль хезмәт күрсәтү системасын үстерү; дәүләти-хосусый партнёрлык һәм инновацион проектлар; социаль нормалар; хәйрия эшчәнлеге мәсьәләләре; социаль ярдәм чаралары методологиясе; халыкның социаль реестрын формалаштыру; күрсәтелә торган социаль ярдәм чараларының функциональ аудиты; адм.-хуҗалык; эшләр башкару; мәгълүмати технологияләр, автоматлаштырылган системалар куллану һәм аларга техник хезмәт күрсәтү; планлаштыру, финанс һәм бухгалтер исәп-хисабы; контроль-ревизия эшләре; дәүләтнең сатып алуы; дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлекләрен; халык б-н эшләү, халыкны эшкә тарту, гражданнар оборонасы һәм мәгълүмати куркынычсызлык секторларын үз эченә ала. Министрлык системасына социаль яклау б-н шөгыльләнүче 52 терр. орган, 159 социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе, халыкны эш б-н тәэмин итүче 52 үзәк керә. ТР Президентына, ТР МКна буйсына.

Министрлар: А.Р.Шәфигуллин (2007–14), Э.А.Зарипова (2014 тән) .

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ХЕЗМӘ́Т ҺӘМ МӘШГУЛЬЛЕ́К МИНИ́СТРЛЫГЫ**. Тарихы СССР ЮС Президиумының 1940 ел 17 апрель Указы нигезендә СССР Электростанцияләр халык комис-тының ТАССРда оешкан төстә эшче көчләр туплау буенча вәкаләтле вәкил конторасы, (СССРның 1946 ел 15 март Законы нигезендә СССР Электростанцияләр министрлыгының ТАССРда оешкан төстә эшче кадрлар туплау буенча вәкаләтле вәкил контора-

сы итеп үзгәртелә), РСФСР ХКСның 1945 ел 14 сентябрь карары нигезендә ТАССР ХКСның (1946 дан — МС) халыкны яңа җирләргә күчерү бүлеге һәм СССР МСның 1947 ел 21 май карары нигезендә СССР Хезмәт резервлары министрлыгының ТАССРда оешкан төстә эшче резервлар туплау буенча вәкаләтле вәкил конторасы (ТАССР МСның 1953 ел 26 май карары б-н ТАССР МСның оешкан төстә эшчеләр туплау бүлеге итеп үзгәртелә) оештырылудан һәм ТАССР МСның 1956 ел 22 август карары нигезендә аларның ТАССР МСның халыкны яңа җирләргә күчерү һәм оешкан төстә эшчеләр туплау бүлегенә берләштерелүеннән башлана. Бүлек ТАССР ЮС Президиумының 1967 ел 31 март Указы б-н — ТАССР МСның Хезмәт ресурсларыннан файдалану идарәсе, ТАССР ЮС Президиумының 1976 ел 8 октябрь Указы б-н — ТАССР МСның Хезмәт буенча идарәсе, ТАССР ЮС Президиумының 1979 ел 22 август Указы б-н — ТАССРның Хезмәт буенча дәүләт ком-ты, ТАССР ЮС Президиумының 1988 ел 18 февраль Указы б-н ТАССРның (1992 дән — ТР) Хезмәт һәм социаль мәсьәләләр буенча дәүләт ком-ты, ТР Дәүләт Советының 1996 ел 25 апрель карары б-н — ТРның Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт ком-ты, ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май карары б-н ТР Х.һ.м.м. итеп үзгәртелә. Социаль һәм халыкны эш б-н тәэмин итү өлкәсендә идарә итү һәм дәүләт сәясәтен камилләштерү гамәлләрен башкара. 1980 елларда аның карамагында гомуми бүлек; гаиләләрне яңа җирләргә күчерү һәм оешкан төстә эшчеләр туплау; хезмәт ресурслары һәм халыкны эш б-н тәмин итү; сәнәгать өлкәсендә хезмәт һәм эшче көчләрдән файдалануны контрольдә тоту; төзелештә, транспортта, җитештерү өлкәсенә карамаган тармакларда хезмәт һәм эшче көчләрдән файдалануны контрольдә тоту; агросәнәгать комплексы тармакларында хезмәт һәм эшче көчләрдән файдалануны контрольдә тоту бүлекләре; кадрлар секторы; бухгалтерия; 21 йөз башында хезмәткә түләү; хезмәтне саклау; хокук; ярдәмче-техник; хезмәт өлкәсендә социаль партнёрлык һәм хезмәт мөнәсәбәтләрен коллектив килешүе нигезендә көйләү; берләштерелгән икътисади анализ; дәүләт хезмәт шартлары экспертизасы бүлекләре керә. Башлангыч чорда Министрлык системасына шәһәр һәм район хезмәт бүлекләре (1981 гә кадәр — вәкилләр), хезмәткә урнаштыру бюролары; 1990 еллардан 2005 кә кадәр — шәһәр һәм район халыкны эш б-н тәэмин итү үзәкләре; Респ-ка укыту-методика үзәге керә. ТР Президентына, ТР МКна (1991 гә кадәр — ТАССР МС) һәм РФнең шул ук исемдәге министрлыгына буйсына. ТР Президентының 2007 ел 14 июнь Указы нигезендә гамәлдән чыгарыла, вазифалары *Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына* тапшырыла.

Дәүләт ком-ты рәисләре — И.Д.Мусаев (1979–85), Г.Ш.Гыйләҗев (1985–88), Д.К.Каюмов (1988–96), Б.Ф.Захаров (1996–2001). Министр — Б.Ф.Захаров (2001–07).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ЭКОЛО́ГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫ́Й БАЙЛЫКЛА́Р МИНИ́СТРЛЫГЫ**. ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май карары нигезендә *Татарстан Республикасы Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану дәүләт комитеты* җирлегендә булдырыла. Табигый байлыклар, әйләнә-тирә мохитне саклау, өйрәнү, файдалану, торгызу, экологик иминлек булдыру өлкәсендә җитәкчелек итә һәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыра. Үз эченә эшләр башкару, мәгълүмат-аналитика эшчәнлеге, матди тәэминат идарәләрен; әйләнә-тирә мохит һәм җир асты байлыкларын саклау департаментын; федераль, респ-ка, ведомство программалары һәм инновацион эшчәнлек, әйләнә-тирә мохит һәм табигатьтән файдалану икътисады, җир асты байлыклары икътисады, дәүләт заказы, конкурс буенча сатулар, җыелма анализ, оештыру-норматив тәэминат, мәгълүмати ресурслар һәм технологияләр, атм. һавасын саклау, су ресурсларын саклау һәм судан файдалануны көйләү, җир ресурсларын саклау, җитештерү һәм куллану калдыклары әйләнешен көйләү, әйләнә-тирә мохит мониторингы, биотөрлелек, ТРның максатчан программа проектларын һәм табигатьтән файдалану өлкәсе объектларының дәүләт экологик экспертизасы, лицензияләрне нигезләү материалларының дәүләт экологик экспертизасы, әйләнә-тирә мохиткә йогынты нормалары, углеводород чималы геологиясе, каты файдалы казылмалар геологиясе һәм гидрогеология, җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү, геол. мәгълүмати ресурслар һәм геол. мохит мониторингы, оештыру эшләре, канцелярия, гомуми, исәп-хисап, дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлекләрен ала. Министрлык системасында 2 инспекция, инспектор бүлеге, 9 идарә, 9 дәүләт табигать тыюлыгы (ш.и. *Озын Алан*) бар. ТР Президентына, ТР МКна һәм РФнең шул ук исемдәге министрлыгына буйсына.

Министрлар: Б.Г.Петров (2001–05), И.А.Ларочкина (2005–07), Ә.К.Садретдинов (2007–11), А.Г.Сидоров (2011–15), Ф.С.Габделганиев (2015тән).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ЭЛЕМТӘ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ**, к. *Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ЭНЕРГЕ́ТИКА МИНИ́СТРЛЫГЫ**. ТР Президентының 2010 ел 22 апрель Указы һәм ТР Дәүләт Советының 2010 ел 22 апрель карары нигезендә оештырыла. Җылылык-энергетика комплексы өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәрү һәм идарә итү функцияләрен тормышка ашыра. Үз эченә фаразлау, үсеш, углеводород чималы, каты файдалы казылмалар һәм гидрогеология, энергетика идарәләрен; инновацион үсеш, энергетика стратегиясен тикшерү һәм мониторинг, җылылык-энергетика һәм электр балансларын фаразлау, ресурс балансларын әзерләү, программалар эшләү һәм методология, җылылык-энергетика комплексында мәгълүмати технологияләрне үстерү, җылылык-энергетика комплексы эшчәнлегенә икътисади анализ, инвестиция проектлары, углеводород чималы геологиясе, нефть һәм газ чыгару, углеводород чималы икътисады, нефть химиясе комплексы, каты файдалы казылмалар геологиясе һәм гидрогеология, судан файдалануны көйләү, җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү, мәгълүмати геол. ресурслар һәм геол. мохит мониторингы, электроэнергетика, энергия б-н тәэмин итү һәм энергиянең нәтиҗәлелеге, ягулык инфраструктурасы һәм газ б-н тәэмин итү, оештыру эшләре һәм эшләр башкару, адм.-хуҗалык, мәгълүматлаштыру, хокук, финансларны планлаштыру, исәп-хисап, кадрлар бүлекләрен; дәүләт заказлары, мобилизацион әзерлек, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр секторларын ала. Министрлык системасына җылылык-энергетика комплексы пр-тиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре керә. ТР Президентына, ТР МКна буйсына. ТР Президентының 2012 ел 28 май Указы һәм ТР Дәүләт Советының 2012 ел 28 май карары б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары *Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына, Татарстан Республикасы Тарифлар дәүләт комитетына* тапшырыла.

Министры – И.Ш.Фәрдиев (2010–12).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ЭЧКЕ́ ЭШЛӘ́Р МИНИ́СТРЛЫГЫ**. Тарихы Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советының Казан губерна башкарма ком-ты каршында идарә итү (эчке идарә) бүлеге оештырылудан (1918 елның гыйн.) башлана. Бүлек Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна советы гомуми җыелышының 1918 ел 26 февраль карары нигезендә — Казан Совет Эшче-Крәстиян Респ-касының Эчке эшләр комис-ты; Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна советы башкарма ком-тының 1918 ел 16 май карары һәм Казан губернасы ХКСның 1918 ел 3 июнь карары б-н — Казан губернасының Эчке эшләр комис-ты; Казан губерна рев-цион ком-тының 1918 ел 16 һәм 25 сентябрь карарлары һәм Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы Казан губерна башкарма ком-тының 1918 ел 15 октябрь карары б-н — губерна башкарма ком-тының идарә бүлеге; БҮБК һәм РСФСР ХКСның 1920 ел 27 май Декреты һәм ТАССР ҮБКның 1920 ел 28 сентябрь карары б-н ТАССР Эчке эшләр халык комис-ты итеп үзгәртелә, СССР ҮБК һәм ХКСның 1930 ел 15 декабрь карары һәм ТАССР ҮБК һәм ХКСның 1930 ел 20 декабрь карарлары б-н гамәлдән чыгарыла (вазифалары ТАССР ҮБКна, ТАССР ХКСна, ТАССР Юстиция халык комис-тына, ТАССР Коммуналь хуҗалык халык комис-тына тапшырыла), СССР ҮБКның 1934 ел 10 июль карары б-н СССР Эчке эшләр халык комис-тының ТАССР буенча идарәсе, ТАССР ҮБКның 1937 ел 20 март карары б-н кабат ТАССР Эчке эшләр халык комис-ты буларак

торгызыла. Халык комис-ты элек гомуми адм. күзәтчелек, рев-цион тәртип һәм гражданнарның куркынычсызлыгын тәэмин итү, совет төзелеше, милиция, җинаятьчеләрне эзләү, ЗАГСлар, янгыннан саклану, коммуналь хезмәтләр һәм ябылуда тоту урыннары б-н җитәкчелек итә. Аңа түбәндәге бурычлар йөкләтелә: хөкүмәт карарларын һәм күрсәтмәләрен тормышка ашыру, гражданлык хәле актларын теркәү, махсус предметлар һәм материаллар б-н сәүдәгә күзәтчелек итү, җинаятьчеләрне эзләү һәм алдан сорау алулар үткәрү, җинаятьчеләрнең исәбен алу, җинаятьчелекне өйрәнү, хезмәт б-н төзәтү сәясәте мәсьәләләрен эшләү, чит илгә чыгу өчен паспортлар бирү, совет аппараты эшчәнлегенә күзәтчелек итү һ.б. 1934 елдан дәүләт куркынычсызлыгын (1943 кә кадәр), җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать милкен саклау, гражданлык хәле актларын теркәү һ.б. б-н шөгыльләнә. Аның составына адм. комиссия; милиция (канцелярия; хуҗалык командасы, адм.-оештыру, тәэминат бүлекләре; сан. бүлеге; команда составы резервы; милиция командирлары мәктәбе); иректән мәхрүм итү урыннары (канцелярия; адм.-пенитенциар, тәэминат бүлекләре; эшкә билгеләү комиссиясе) баш идарәләре; эшләр башкару (хуҗалык һәм архив бүлекчәләре; финанс бүлеге), адм.-оештыру (адм., мәгълүмат-стат. бүлекләре; ЗАГС), җинаятьчеләрне эзләү (канцелярия; актив, яшерен, хисап-теркәү бүлекләре), коммуналь хуҗалык (финанс-хисап, торак, җир, сан.-хуҗалык, транспорт, төзелеш-техника, янгыннан саклану, тәэминат бүлекләре); халыкны эвакуацияләү (1920–22), почта һәм телеграф (1920–22) идарәләре; 1937 дән — дәүләт куркынычсызлыгы (1943 кә кадәр), милиция идарәләре; адм.-хуҗалык, иректән мәхрүм итү урыннары һәм лагерьлар, хезмәт б-н төзәтү колонияләре, төрмәләр, транспорт, аерым, махсус, автотехника, янгыннан саклану, гражданлык хәле актлары, финанс, элемтә, кадрлар, архив бүлекләре һ.б. керә. ТАССР ҮБКна (1938 гә кадәр) , ТАССР ХКСна, РСФСР Эчке эшләр халык комис-тына (1930 га кадәр), СССР Эчке эшләр халык комис-тына (1934–46) буйсына.

ТАССР Эчке эшләр халык комис-ты ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы б-н — ТАССР Эчке эшләр министрлыгы, ТАССР ЮС Президиумының 1962 ел 5 сентябрь Указы б-н — ТАССР Җәмәгать тәртибен саклау министрлыгы, ТАССР ЮС Президиумының 1968 ел 3 декабрь Указы б-н — кабат ТАССР (1990нан — ТССР, 1992 дән — ТР), РФнең 2011 ел 7 февраль Федераль законы нигезендә РФнең ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы итеп үзгәртелә. Министрлык җинаятьчелек б-н көрәшү, җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү, җинаятьчелекне һәм хокук бозуларны кисәтү һәм булдырмый калу б-н шөгыльләнә. Секретариат, штаб, криминаль милицияне, җәмәгать куркынычсызлыгы милициясен, баш тикшерү идарәсен, кадрлар аппаратын, тыл хезмәтен, үз куркынычсызлык идарәсен, хокукый тәэминат бүлеген үз эченә ала. ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы системасына эчке эшләр органнарының шәһәр һәм район бүлекчәләре керә. РФ Эчке эшләр министрлыгы структурасына керә һәм аңа буйсына.

Халык комиссарлары һәм министрлар: А.Ю.Измайлов (1920–21), М.Ә.Әхмәтшин (1921–22), Х.А.Чанышев (1922–24), М.У.Усманов (1924–26), Н.В.Петров (1926–27), Х.И.Моратхуҗин (1927–29), Г.Б.Баһаветдинов (1929 – июнь, 1930), А.Б.Мукминев (июль–дек., 1930), П.Г.Рудь (март–июль, 1937), А.М.Алемасов (июль–сент., 1937), В.И.Михайлов (1937 нең сент. – 1939), Е.М.Морозов (1939–41), А.Г.Габитов (1941–43), П.Н.Горбулин (1943–48), Ш.З.Ченборисов (1948–50), М.И.Хохлов (1950–52), М.А.Запевалин (1952–53), П.П.Семёнов (1953–54), С.Җ.Япиев (1954–78), Н.И.Демидов (1978–83), С.И.Кирилов (1983–93), И.Г.Галимов (1993–98), Ә.Ә.Сәфәров (1998–2012), А.В.Хохорин (2012 дән).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ЭШ-ХЕЗМӘ́Т ДОКУМЕНТЛАРЫ́ ДӘҮЛӘ́Т АРХИВЫ́**. ТР МКның 1994 ел 26 декабрь карары нигезендә Татарстан Респ-касының Эш-хезмәт документларын саклау үзәге буларак оештырыла, ТР МКның 1999 ел 30 март карары б-н хәзерге исемендә. Максаты: гражданнарны социаль һәм хокукый яклау, министрлыкларда, дәүләт ком-тларында, пр-тиеләрдә, башка төр рәсми оешмаларда, колхоз-совхозларда һ.б.да эшләүчеләрнең шәхси эшләрен саклау. ТР МКның *Баш архив идарәсенә* буйсына. ТРдагы үзгәртеп корылган һәм ябылган учреждение һәм оешмаларның (ком-тлар, министрлыклар, заводлар, фабрикалар, оешмалар, АҖлар, дәүләт пр-тиеләре, фәнни-тикшеренү ин-тлары, югары һәм урта уку йортлары, банклар һ.б.) аерым шәхесләренә бәйле документларны кабул итә, саклый, терки һәм файдалана. ТР Эш-хезмәт документлары дәүләт архивында түбәндәгеләр туплана: оештыру-боеру документлары (боерыклар, күрсәтмәләр, аерым шәхесләрне эшкә кабул итү, икенче эшкә күчерү һәм эштән азат итү мәсьәләсе буенча карарлар); уку йортларындагы дәүләт имтиханнары комиссиясе утырышларының беркетмәләре; аерым шәхесләрне исәпкә алу документлары (укучыларның китаплары, журналлары, исемлекләре, картотекалары, исемнәре атап язылган китаплары һ.б.); хезмәт хакы бирү өчен нигез булган финанс документлары (шәхси счётлар һәм исәп-хисап — акча түләү исемлекләре); эшче һәм хезмәткәрләрнең шәхси эш-делолары, шәхси карточкалары; һәлакәт булган урыннарда тикшерү документлары (актлар, бәяләмәләр, беркетмәләр); аттестация һәм тарификация документлары; хезмәт контрактлары һәм килешүләре; шәхси эшләр составына кертелмәгән рәсми һәм шәхси документлар (хезмәт кенәгәләре, дипломнар, аттестатлар, таныклыклар); зарарлы һөнәрләр хезмәткәрләренең табель һәм нарядлары. Аерым шәхесләргә бәйле учреждение күрсәтмәләре һәм боерыкларында шәхесләрне эшкә кабул итү, икенче эшкә күчерү һәм эштән азат итү очраклары, аның бүләкләре, премияләре, шелтәләре, хезмәт хакындагы үзгәрешләр, командировкалар, бәяләмәләр турында мәгълүматлар чагыла. Шәхес турында күбрәк мәгълүмат шәхси счётында һәм расчёт кенәгәләрендә була. Шәхси счёт формулярында шәхеснең хезмәт урыны, вазифасы, эшкә алыну вакыты: эш барышы, дәрәҗәсе, хезмәт хакының күләме, төрле түләүләр, ялы һ.б. турында мәгълүматлар күздә тотыла. Шәхесләрнең техникумнарда, комб-тларда, университетларда, институтларда, курсларда укулары турындагы документлары арасында уку карточкалары, өлгереш исемлеге, квалификация комиссиясе утырышларының беркетмәләре, дәүләт имтихан комиссиясе утырышларының беркетмәләре, диплом проектларын һәм эшләрен яклау комиссиясе беркетмәләре, яшь белгечләрне эшкә урнаштыру комиссиясе беркетмәләре, эшкә урнаштыру планнары, укучылар һәм тыңлаучылар исемлеге һ.б. бар. 2012 елның 1 гыйнварына архивта 1244 фонд, 374789 саклау берәмлеге исәпләнә (1916–2011).

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ЮГАРЫ́ МӘХКӘМӘСЕ́**, ТРның югары мәхкәмә органы. Гомуми вәкаләтле мәхкәмәләр эшчәнлегенә һәм аларның гадел хөкем итүенә бәя бирә. 1922 елның 12 декабрендә БҮБКның 9 нчы чакырылыш 4 нче сессиясенең 1922 ел 31 октябрь карары нигезендә ТАССР Өлкә мәхкәмәсе буларак оештырыла, 1923 нең 17 октябрендә БҮБК һәм РСФСР ХКСның 1923 ел 5 сентябрь карары б-н ТАССР Баш мәхкәмәсе итеп үзгәртелә. Җинаять һәм гражданлык эшләре буенча беренче инстанция мәхкәмәсе , кассация мәхкәмәсе сыйфатында, ш.у. халык судьялары һәм тикшерүчеләргә мәхкәмә күзәтчелеге тәртибендә ревизия-контроль эшчәнлеге б-н шөгыльләнә, респ-ка халык мәхкәмәләре б-н турыдан-туры җитәкчелек итә. Рәис, җинаять һәм гражданлык эшләре буенча рәис урынбасарлары, ТАССР ҮБК тарафыннан сайланган мәхкәмә әгъзаларыннан тора. Пленум, Президиум, җинаять һәм гражданлык эшләре буенча мәхкәмә һәм кассация коллегияләре, махсус коллегия (1934 тән), мәгълүмат-стат. һәм оештыру-инструкторлар бүлекләре составында эшли. ТАССР ҮБКның 1937 ел 16 февраль карары б-н ТАССР Баш мәхкәмәсе ТАССР (1990 нан — ТССР, 1992 дән — ТР) Югары мәхкәмәсе итеп үзгәртелә. Ул Рәис, Рәис урынбасарлары, мәхкәмә әгъзалары һәм халык утырышчыларыннан тора .

ТР Ю.м. судьялары, РФ Югары мәхкәмәсе рәисе тәкъдиме б-н һәм ТР Дәүләт Советы б-н килешенеп, вәкаләт вакыты чикләнмәгән хәлдә, (элек, 1958 гә кадәр, респ-каның ЮС тарафыннан 3 елга, 1958 — 90 да — 5, 1990 нан — 10 елга сайлана) РФ Президенты тарафыннан билгеләп куела. ТР Ю.м. үз эшчәнлеген Президиум (1954 тән), гражданлык (рәис һәм 17 судья) һәм җинаять эшләре (рәис һәм 44 судья) буенча мәхкәмә коллегияләре б-н алып бара. Судья һәм утырышчылар — бәйсез һәм фәкать Законга гына буйсына. ТР Ю.м. законнар чыгаруда катнашырга хокуклы; җинаять һәм гражданлык эшләрен бе-

ренче инстанция мәхкәмә сыйфатында, кассация, күзәтчелек итү тәртибендә, яңа билгеле булган фактларга бәйле рәвештә карый; район һәм шәһәр мәхкәмәләренең эшчәнлегенә күзәтчелек итә; мәхкәмә практикасын өйрәнә һәм гомумиләштерә; мәхкәмә статистикасына анализ ясый. ТР Ю.м. судьясы карарлары, мәхкәмә коллегияләре хөкемнәре һәм билгеләмәләре б-н риза булмаган очракта, процессуаль законнарга нигезләнеп, РФ Югары мәхкәмәсенә шикаять бирергә һәм ризасызлык белдерергә мөмкин.

Рәисләр: Ш.З.Саттаров (1922–23), К.Х.Хәйруллин (1923–25), Р.Б.Солтанов (1925–27), С.Х.Моратов (1928–30), Н.А.Алиев (1930–32), Х.Н.Нәбиуллин (1932–34), Г.Г.Сәгыйтов (1934–37), Г.Х.Шәмсетдинов (1938–41), К.С.Сафиуллин (1941–50), Ф.Л.Токарев (1950–54), А.К.Орлов (1954–58), Я.Н.Насыйбуллин (1958–65), А.Д.Басов (1965–69), С.А.Беглова (1969–85), Г.М.Баранов (1985–2011), И.И.Гыйләҗев (2011дән) .

*М.М.Мәүләтшин.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ЮГАРЫ́ СОВЕТЫ́**, респ-ка (1990 елга кадәр — ТАССР ЮС, 1990 нан — ТССР ЮС, 1992 дән — ТР ЮС) дәүләт хакимиятенең югары органы. Беренче тапкыр 1938 елда сайлана. *Татарстан АССР Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советының Үзәк башкарма комитетын* алыштыра. Бер палаталы, 4 елга, 1978 дән 5 елга яшерен тавыш бирү рәвешендә гомуми, тигез һәм туры-дан-туры сайлау хокукы нигезендә сайланган башта 143 депутаттан, 1947 дән — 149, 1951 дән — 184, 1955 тән — 187, 1959 дан — 194, 1963 тән — 200, 1967 дән — 207, 1975 тән — 220, 1980 нән — 250 депутаттан тора. ТАССР (1937, 1978) һәм ТР (1992) Конституцияләре нигезендә ЮС респ-ка Конституциясен, башка законнарны кабул итә һәм аларга үзгәрешләр кертә; милли-дәүләт һәм адм.-терр. төзелеш мәсьәләләре буенча карарлар кабул итә; дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнарын, иҗтимагый оешмалар төзи һәм аларның эшчәнлеге тәртибен билгели; респ-ка чикләрен үзгәртә; респ-ка халык хуҗалыгы үсешенең дәүләт планнарын, респ-ка күләмендәге иң әһәмиятле социаль-икътисади үсеш программаларын, дәүләт бюджетын раслый һәм аларның үтәлешенә контрольлек итә; респ-каның дәүләт бүләкләрен булдыра һәм мактаулы исемнәрен билгели. ЮС хөкүмәт (1946 га кадәр — ХКС, 1946–91 дә — МС, 1991 дән — МК) оештыра, респ-ка Прокурорын билгели, Югары мәхкәмә, район һәм шәһәр халык мәхкәмәләренең халык судьяларын, Югары арбитраж мәхкәмәсен сайлый; респ-каның халык депутатларын сайлауларны билгели; ЮС Рәисен һәм Рәиснең ике (1951–80 дә — дүрт) урынбасарын, ЮСның даими һәм вакытлы комиссияләрен, Президиумын, Парламент контроле ком-тын сайлый. 1989 га кадәр ТАССР ЮС сессияләре кимендә елга ике тапкыр үткәрелә, аларның һәркайсы берничә көн дәвам итә (1989 га кадәр). 1989 ның 4 ноябрендә ТАССР Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелү һәм 1992 дә ТР Конституциясе кабул ителү б-н, ЮСка дәүләт хакимиятенең даими эшләүче закон чыгару һәм контроль органы статусы бирелә. ТР ЮСның төп актлары — законнар, карарлар, декларацияләр.

Респ-ка ЮС Рәисе ЮС утырышларын алып бара, сессияләрдә кабул ителгән законнарга һ.б. документларга имза куя, 1990–91 дә — ТССРның иң югары вазифаи заты, 1991 дән ЮСның ЮС һәм аның Президиумы эшчәнлеген оештыручы иң югары вазифаи заты булып тора.

Респ-каның ЮС Президиумы — аның даими эшләүче органы, сессияләр арасында, Конституция б-н каралган чикләрдә, дәүләт хакимиятенең иң югары органы вазифаларын гамәлгә ашыра, 1989 дан ЮС эшләрен оештыра һәм аның карамагындагы башка мәсьәләләрне карый. Указлар чыгара һәм карарлар кабул итә. Президиум Рәисе, аның ике урынбасары, Секретарь һәм 11 әгъзадан (1989 га кадәр), 1990 нан — Рәис, Рәис урынбасарлары, Секретарь, даими комиссия рәисләре, Парламент контроле ком-ты һәм респ-ка ЮСның башка депутатларыннан тора .

Чакырылышлар: 1 нче (вәкаләтләре озайтылган) — 1938–47; 2 нче — 1947–51; 3 нче — 1951–55; 4 нче — 1955–59; 5 нче — 1959–63; 6 нчы — 1963–67; 7 нче — 1967–71; 8 нче — 1971–75; 9 нчы — 1975–80; 10 нчы — 1980–85; 11 нче — 1985–90; 12 нче — 1990–95 еллар.

ТАССР ЮС Президиумы Рәисләре: Г.А.Динмөхәммәтов (1938–51), С.Н.Низамов (1952–59), К.Ф.Фасиев (1959–60), С.Г.Батыев (1960–83), Ә.Б.Баһаветдинов (1983–86), Ш.Ә.Мостаев (1986–90).

ТАССР (ТССР, ТР) ЮС Рәисләре: С.Ә.Мөхәммәтов (1938–42), Г.Г.Измайлова (1943–47), А.Г.Долотказин (1947–51), Г.Г.Измайлова (1951–55), М.В.Замова (1955–59), А.В.Бадыгов (1959–63), М.И.Абдрахманов (1963–71), Р.Ш.Нигъмәтуллин (1971–80), М.З.Зәкиев (1980–90), М.Ш.Шәймиев (1990–91), Ф.Х.Мөхәммәтшин (1991–95).

ТАССРның 1 нче чакырылыш ЮС 1938 нең 25 июнендә сайлана (хәрби чор шартларына бәйле рәвештә вәкаләтләр срогы 1947 гә кадәр озайтыла).

1 нче сессиядә (1938 нең 26–29 июле) ТАССР ЮС Рәисе һәм Рәиснең ике урынбасары; ТАССР ЮС Президиумы; ТАССР ЮС даими комиссияләре — мандат, бюджет, закон фаразлары сайлана; хөкүмәт — 19 кешедән торган ТАССР ХКС оештырыла.

2 нче сессиядә (1939 ның 13–17 авг.) 1939 елга ТАССРда Дәүләт бюджеты һәм 1938 дә ТАССР Дәүләт бюджеты үтәлеше турында хисап; хезмәт ияләренең район, шәһәр, авыл һәм посёлок советлары депутатларын сайлаулар турында Нигезләмә; ТАССР ЮС Президиумы Указы раслана; ТАССР Югары мәхкәмәсе сайлана.

Шуннан соң респ-каның барлык чакырылыш ЮС сессияләрендә даими рәвештә алдагы елга Дәүләт бюджеты һәм узган елга Дәүләт бюджеты үтәлеше турында хөкүмәт хисаплары; ТАССР (ТР) ЮС Президиумы указлары раслана; 1957 дән башлап, Татарстан халык хуҗалыгы үсешенең еллык һәм бишьеллык Дәүләт планнары карала. Моннан тыш түбәндәге мәсьәләләр тикшерелә:

- 1 нче чакырылыш ЮС сессияләрендә: җирле чимал һәм калдыклардан киң куллану товарлары һәм азык-төлек җитештерү; хәрби хезмәткәрләр гаиләләренә ярдәм итү (6 нчы сессия, 1943 нең 10–11 июле); гомуми белем бирү мәктәпләрендә 1943/44 уку елына йомгак һәм яңа уку елына әзерлек; респ-ка колхозларында һәм совхозларында терлекләр өчен азык базасы булдыру һәм атларның баш санын саклау һәм арттыру чаралары (7 нче сессия, 1944 нең 20–23 июле); мәктәп яшендәге балаларны гомуми мәҗбүри укыту турындагы Закон үтәлеше һәм мәктәпләрне яңа 1946/47 уку елына әзерләү (10 нчы сессия, 1946 ның 17–19 июле) турында ;
- ТАССРның 2 нче чакырылыш ЮС (1947 нең 9 февралендә сайлана) сессияләрендә: 1946–50 елларда ТАССР халык хуҗалыгын торгызу һәм үстерүнең бишьеллык планы (1 нче сессия, 1947 нең 17–19 марты); ТАССРда мәктәп яшендәге балаларны гомуми мәҗбүри укыту турындагы Закон үтәлеше (4 нче сессия, 1949 ның 14–15 нояб.) турында ;
- ТАССРның 3 нче чакырылыш ЮС (1951 нең 18 февралендә сайлана) сессияләрендә: респ-кадагы мәдәни-агарту учреждениеләренең торышы һәм аларның эшен яхшырту чаралары (2 нче сессия, 1952 нең 14–15 февр.); ТАССРда халык мәгарифенең торышы һәм аны яхшырту чаралары (4 нче сессия, 1952 нең 9–10 дек.); ТАССР авылларында яшәүче халыкка мед. хезмәте күрсәтүне яхшырту чаралары (6 нчы сессия, 1953 нең 22 дек.); ТАССР Дәүләт флагы (7 нче сессия, 1954 нең 22–23 июне); ТАССР авыл советларының торышы һәм аларның эшен яхшырту чаралары (8 нче сессия, 1954 нең 21 дек.) турында;
- ТАССРның 4 нче чакырылыш ЮС (1955 нең 27 февралендә сайлана) сессияләрендә: респ-када юл хуҗалыгының торышы һәм аны яхшырту чаралары (2 нче сессия, 1955 нең 23–24 дек.); респ-каның җирле һәм кооперация сәнәгатенең торышы һәм аларның эшен яхшырту чаралары (4 нче сессия, 1956 ның 12 дек.); «Колхозларның алга таба үсеше һәм МТСны үзгәртеп кору турында» ТАССР ЮС Законы үтәлешенең торышы (7 нче сессия, 1958 нең 10 дек.) турында;
- ТАССРның 5 нче чакырылыш ЮС (1959 ның 1 мартында сайлана) сессияләрендә: мәктәпнең тормыш б-н бәйләнешен ныгыту һәм ТАССРда халык мәгарифен алга таба үстерү (2 нче сессия, 1959 ның 19 мае); ТАССР ЮС депутатын чакыртып алу (3 нче сессия, 1960 ның 6–7 гыйн.); хезмәт ияләре депутатларының район, шәһәр, авыл һәм посёлок советлары депутатын чакыртып алу (5 нче сессия, 1961 нең 30–31 гыйн.); респ-ка мәдәни-агарту учреждениеләренең торышы һәм аларның эшен яхшырту чаралары (6 нчы сессия, 1961 нең 21 нояб.); респ-када халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүне яхшырту чаралары; ТАССРның табигатен саклау; ТАССР һәм

респ-ка хезмәт ияләре депутатлары җирле советларының бюджет хокуклары (8 нче сессия, 1962 нең 5–6 июле); мәктәпнең тормыш б-н бәйләнешен ныгыту турындагы Закон үтәлешенең барышы һәм ТАССРда халык мәгарифе системасын алга таба үстерү (9 нчы сессия, 1962 нең 13–14 нояб.) турында ;

- ТАССРның 6 нчы чакырылыш ЮС (1963 нең 3 мартында сайлана) сессияләрендә: респ-када юл хуҗалыгының торышы һәм аны яхшырту чаралары (1 нче сессия, 1963 нең 21–22 марты); хезмәт ияләре җирле советлары депутатларының колхоз әгъзаларына пособиеләр һәм пенсияләр, ш.у. социаль тәэминат органнары эшен яхшырту чаралары турында Закон кабул ителү б-н бәйле (3 нче сессия, 1964 нең 2 окт.); җирле советларның Бөек Октябрь соц. рев-циясенең 50 еллыгына әзерләнү б-н бәйле бурычлары; респ-када балигъ булмаганнар арасында тәрбия эшләрен яхшырту чаралары (5 нче сессия, 1965 нең 26 окт.); ТАССРда халык контроле органнары (6 нчы сессия, 1966 ның 18–19 гыйн.) турында ;

- ТАССРның 7 нче чакырылыш ЮС (1967 нең 12 мартында сайлана) сессияләрендә: респ-када көнкүреш хезмәте күрсәтүнең торышы һәм аны яхшырту чаралары (1 нче сессия, 1967 нең 31 март–1 апр.); ТАССРда мәдәни төзелешне алга таба үстерү чаралары (3 нче сесия, 1968 нең 16–17 мае); респ-када азык-төлек сәнәгатенең торышы һәм аны алга таба үстерү чаралары; хезмәт ияләре депутатларының авыл, посёлок советлары (4 нче сессия, 1968 нең 21–22 нояб.); җирдән рациональ файдалану, туфракның уңдырышлылыгын арттыру һәм җир турындагы законнарны үтәү буенча җирле советларның бурычлары (6 нчы сессия, 1969 ның 20–21 нояб.) турында ;

- ТАССРның 8 нче чакырылыш ЮС (1971 нең 13 июнендә сайлана) сессияләрендә: КПССның 24 нче съезды карарларын үтәү буенча ТАССР советларының бурычлары (1 нче сессия, 1971 нең 7–8 июле); ТАССР хезмәт ияләре депутатларының район советы; ТАССР хезмәт ияләре депутатларының шәһәрдәге район советы (2 нче сессия, 1971 нең 21–22 дек.); массакүләм ихтыяҗга ия товарлар җитештерү буенча респ-ка халык хуҗалыгын үстерү планының үтәлеше (3 нче сессия, 1972 нең 8 июне); респ-ка торак фондының торышы, аннан файдалану, сакланышын тагын да яхшырту чаралары (5 нче сессия, 1973 нең 28–29 июне); респ-ка автомобиль юлларының торышы, юллар төзү һәм аларның кулланылышын яхшырту чаралары (7 нче сессия, 1974 нең 21 мае) турында ;

- ТАССРның 9 нчы чакырылыш ЮС (1975 нең 15 июнендә сайлана) сессияләрендә: ТАССРда гомуми урта белем бирүгә күчүне төгәлләү чаралары, респ-када уңайлы булмаган һава шартлары нәтиҗәләрен кисәтү чаралары (1 нче сессия, 1975 нең 27 июне); КПССның 25 нче съезды карарларын үтәү буенча ТАССР хезмәт ияләре депутатлары советларының бурычлары (3 нче сессия, 1976 ның 17 июне); КПССның 25 нче съезды карарлары яктылыгында ТАССР хезмәт ияләре депутатлары советларының респ-ка халкына иҗтимагый-хезмәт һәм әхлак тәрбиясе бирүне тагын да яхшырту буенча бурычлары (5 нче съезд, 1977 нең 26 мае); СССР Конституциясе проекты һәм ТАССР хезмәт ияләре депутатлары советларының КПСС ҮКның май (1977) Пленумы карарларына бәйле бурычлары (6 нчы сессия, 1977 нең 23 июне); КПСС ҮКның октябрь (1977) Пленумы нәтиҗәләре, СССР ЮСның чираттан тыш 7 нче сессиясе һәм респ-ка халык депутатлары советларының «СССР Конституциясе (Төп Законы) проекты һәм аны бөтен халык тикшерүенә кую нәтиҗәләре турында» докладына бәйле рәвештә бурычлары (7 нче сессия, 1977 нең 23 нояб.) турында; ТАССР Конституциясе (Төп Законы) кабул ителә (9 нчы сессия, 1978 нең 30–31 мае); ТАССР ЮСна сайлаулар; ТАССР Дәүләт гербы; ТАССР Дәүләт флагының график сурәтен раслау турында (11 нче сессия, 1978 нең 22 дек.); халык депутатлары советларының респ-када шәһәрләр һәм торак пунктлар төзү һәм төзекләндерү эшен тагын да яхшырту буенча халык депутатлары советы мәсьәләләре турында; ТАССР ЮСна һәм район, шәһәр, посёлок, авыл советларына чираттагы ТАССР халык депутатлары сайлауларны уздыру (12 нче сессия, 1979 ның 12 июне); ТАССР МС; җирле советларга халык депутатлары сайлау (13 сессия, 1979 ның 23 авг.) турында .

- ТАССРның 10 нчы чакырылыш ЮС (1980 нең 24 февралендә сайлана) сессияләрендә: ТАССР ЮС Регламенты; халык куллануы товарлары җитештерүне арттыру һәм аларның сыйфатын яхшырту чаралары турында (1 нче сессия, 1980 нең 20 марты); КПССның 26 нчы съезды карарларыннан чыгып, ТАССР халык депутатлары советларының бурычлары (3 нче сессия, 1981 нең 2 июне); КПССның 26 нчы съезды карарлары яктылыгында респ-када юл төзү эшләрен тагын да яхшырту (5 нче сессия, 1982 нең 10 июне); респ-када КПСС ҮК һәм СССР МСның «Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүне тагын да үстерү һәм яхшырту турында» 1983 ел 24 март карарын тормышка ашыру буенча чаралар күрү (7 нче сессия, 1983 нең 10 июне); СССРның 11 нче чакырылыш ЮС сессиясе, КПСС ҮКның апрель (1984) Пленумы карарларыннан чыгып, халык депутатлары советларының бурычлары (9 нчы сессия, 1984 нең 28 июне) турында ;

- ТАССРның 11 нче чакырылыш ЮС (1985 нең 24 февралендә сайлана) сессияләрендә: Партиянең 26 нчы съезды һәм КПСС ҮКның шуннан соңгы Пленумнары карарлары яктылыгында ТАССР шәһәрләрендә һәм авылларында коммуналь хуҗалык объектларын алга таба үстерү һәм аларның тотрыклы эшчәнлеген тәэмин итү буенча халык депутатлары советлары, министрлыклар һәм ведомстволарның бурычлары турында (1 нче сессия, 1985 нең 22 марты); КПССның 27 нче съезды карарларыннан чыгып, ТАССР халык депутатлары советларының бурычлары (3 нче сессия, 1986 ның 18 апр.); КПССның 27 нче съезды карарлары яктылыганда ТАССР халык депутатлары советларының үз эшчәнлекләренең стилен һәм эш алымнарын камилләштерү, респ-каның социаль-икътисади үсешен тагын да арттыру һәм җаваплылыгын көчәйтүне тизләтүдәге роле юнәлешендәге эшләре (6 нчы сессия, 1987 нең 22 мае), ТАССРда халык хуҗалыгы б-н идарә итү структурасын камилләштерү (8 нче сессия, 1988 нең 8 апр.); ТАССР Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү; ТАССР халык депутатларын һәм җирле советларга халык депутатлары сайлау; Татарстан атом электростанциясе (11 нче сессия, 1989 ның 3–4 нояб.); ТАССРның үзидарәгә һәм үз-үзен финанслауга күчеш концепциясенең төп нигезләмәләре (12 нче сессия, 1989 ның 8 дек.) турында .

1990 ның март–апрелендә ТРның 12 нче чакырылыш ЮС сайлана, аның эшчәнлегендә илнең социаль-сәяси, икътисади һәм мәдәни-идеологик нигезләрен үзгәртеп кору б-н бәйле зур үзгәрешләр чагылыш таба .

1 нче сессиядә (1990 ның 11–17 апр.) ТАССР ЮС Рәисе һәм Рәиснең ике урынбасары сайлана; ТАССР ЮСның: мандат, планлаштыру һәм бюджет-финанс; законнар чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм өстенлекләр бирү мәсьәләләре; халык депутатлары советы эшчәнлеге, идарә, үзидарә һәм хәбәрдарлык үсеше; милли мәсьәләләр һәм мәдәният; сәнәгать, халык куллануы товарлары, транспорт, элемтә, сәүдә һәм халыкка хезмәт күрсәтү; аграр мәсьәләләр; төзелеш, төзелеш материаллары җитештерү, архит-ра, торак-коммуналь төзелеш һәм төзекләндерү; халык мәгарифе, фән һәм тәрбия мәсьәләләре; халыкның сәламәтлеген саклау, шәфкатьлелек, ветераннар, хатын-кызлар, гаиләне ныгыту, аналар һәм балалар мәсьәләләре; экология һәм табигый ресурслардан рациональ файдалану; яшьләр эшләре, физик культура һәм спорт даими комиссияләре; ТАССР ЮС Президиумы; ТАССР Халык контроле ком-ты, ТАССР Югары мәхкәмәсе; ТАССР Дәүләт арбитражы; ТАССР район, шәһәр халык мәхкәмәләре халык судьялары сайлана — 28 әгъза составында хөкүмәт — ТАССР МС оештырыла; Татарстан АЭС объектларын төзүне туктату, Түбән Кама ГЭС сусаклагычының биеклеге турында карарлар кабул ителә; ТАССР ЮСның вакытлы Регламенты раслана.

2 нче сессиядә (1990 ның 27–31 авг.) ТССРның дәүләт суверенлыгы турында Декларация; ТССР ЮС Регламенты; ТССР ЮСның даими комиссияләре, ТССР халык депутатының статусы; ТССР ЮСнда кабул ителгән ТССР законнарын һ.б. актларны бастырып чыгару һәм аларны гамәлгә керү тәртибе, ТССРда халык хакимияте нигезләре, ТССР Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында законнар; Татарстан ССР төзелү көне; дәүләт суверенитеты турындагы Декларациядән чыгып, ТССР МСның бурычлары; ТССР халык контроле органнарын гамәлдән чыгару турында карарлар кабул ителә; ТССР ЮС Президиумына һәм даими комиссияләр составына үзгәреш-

ләр кертелә, ТССР Конституция комиссиясе оештырыла.

3 нче сессиядә (1990 ның 10–14 дек., 1991 нең 6–8 февр.) ТССР ЮС Президиумы составына, ТССР МС структурасына үзгәрешләр кертелә; 1990 да ТССР Дәүләт икътисади һәм социаль үсеш планы үтәлешенең барышы турында хисап хуплана; 1991 елга ТССР Респ-ка бюджеты һәм 1989 елга ТАССР Дәүләт бюджеты үтәлеше турында хисап раслана; ТССРда конституция күзәтчелеге, җирле советлар халык депутатларының, ТССР халык депутатларының статусы; колхозлар, совхозлар, сәнәгать, транспорт, төзелеш, кооператив һ.б. пр-тие һәм хуҗалык оешмалары тарафыннан җирле автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, ремонтлау һәм тәртиптә тотуга акча күчерү турында; ТССР дәүләт контроле турында; ТССР Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында законнар; базар икътисадына күчү барышында ТССР халык хуҗалыгына дәүләт идарәсен тәэмин итү чаралары, ТССР терр-ясендә пр-тиеләр һәм оешмаларны дәүләттән аеру һәм хосусыйлаштыру актларын гамәлгә яраксыз дип игълан итү, халык хуҗалыгын тотрыкландыру һәм ТССРда базар мөнәсәбәтләренә күчү программасы раслана; ТССР Конституция күзәтчелеге ком-ты, ТССР Дәүләт (парламент) контроле ком-ты сайлана.

4 нче сессиядә (1991 нең 16–19 апр., 13–14, 27 мае) ТССР Конституциясенә, 1991 елга ТССРның Респ-ка бюджеты турындагы Законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелә; ТССР Җир кодексы турында; җир реформасы, крәстиян (фермер) хуҗалыгы, ТССР Президентын сайлау турында законнар; ТССР терр-ясендә РСФСР Президентын сайлауны үткәрү турында карар кабул ителә; ТССР Конституция күзәтчелеге ком-тының җирле советлар депутатлары һәм ТССР халык депутатларының депутатлык кагылгысызлыгы турында бәяләмәсе тыңлана; ТССР Югары мәхкәмәсе әгъзалары сайлана.

5 нче сессиядә (1991 нең 4–6 июле) ТССР Президентын сайлау нәтиҗәләре хуплана; ТССР Президенты тарафыннан ант бирелә; ТССР Президенты вазифасына керешү, ТССР Президентының абруен һәм намусын саклау турында законнар; ТССРдагы иҗтимагый оешма уставларын теркәү тәртибе турында карар кабул ителә; ТССР Конституциясенә өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертелә; ТССР ЮС Рәисе, ТССР вице-президенты, ТССР Премьер-министры, 27 кешедән торган хөкүмәт — ТССР МК сайлана.

6 нчы сессиядә (1991 нең 29 авг.) Президент, ЮС Рәисе, ТССР Премьер-министрының хәзерге вазгыять турындагы мәгълүматы тыңлана; 30 августны — Татарстан ССР төзелгән көнне — бәйрәм көн дип игълан итү турында Закон; ТССР ЮСның Татарстан халкына Мөрәҗәгате (1991нең 19–21 августында СССРда дәүләт түнтәрелеше ясарга омтылыш — гадәттән тыш хәлләр буенча Дәүләт ком-ты — ГКЧП — б-н бәйле рәвештә) кабул ителә.

7 нче сессиядә (1991 нең 15–25 окт., 25–29 нояб.) РФ б-н милек бүлү буенча сөйләшүләр алып бару комиссиясе мәгълүматы; ТССР МК хисабы тыңлана; ТССРда милек мәсьәләләре, халыкны эш б-н тәэмин итү; ТССР референдумы; икътисади реформалар үткәрелү чорында респ-када башкарма-идарә органнары эшчәнлеген тәэмин итү турында законнар; Татарстанның дәүләт бәйсезлеге акты; ТССР терр-ясендә РСФСРның «РСФСРда гражданнарга медицина иминиятләштерүе турында» Законының гамәлдә булуы турында карарлар кабул ителә; ТССР Дәүләт флагы турында Нигезләмә раслана; ТССР Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелә; Башкортстан Респ-касы һәм Татарстан ССР арасында Шартнамә раслана.

8 нче сессиядә (1991 нең 23–26 дек., 1992 нең 3–7 һәм 19–21 февр.) ТР Президентының хәзерге вазгыять һәм бәяләрне ирекkә җибәрү шартларында халыкны социаль яклау буенча чаралар турында ТР Президенты докладды тыңлана; ТССР исемен алыштыру, ТРның бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында; ТР гражданнарының акчалата керемнәрен һәм җыелган акчаларын индексацияләү турында, ТРда бәйрәм көннәре турында; ТР юл фонды, ТРда дәүләти һәм коммуналь милекне үзгәртү (дәүләттән аеру һәм хосусыйлаштыру) турында, ТРда исемле хосусыйлаштыру кертемнәре турында; РФ б-н килешү төзелгәнгә кадәр ТРның Респ-ка бюджетын төзү тәртибе турында законнар; 1991 дә ТССРда икътисади һәм социаль үсеш барышы турында; ТРда ТРның дәүләт статусы мәсьәләсе буенча ТРда референдум үткәрү турында карарлар; ТРның БДБ составына керүе турындагы Декларация кабул ителә; ТРның 1992 нең 1 кварталына ТР Респ-ка бюджеты һәм ТССРда 1990 елга һәм 1991 нең 10 аена Респ-ка бюджеты үтәлеше турында хисап; ТР Дәүләт гербы турында Нигезләмә раслана.

9 нчы сессиядә (1992 нең 16 марты) ТРда референдум уздыру мәсьәләсенең асылын аңлату турында карар (1992 нең 21 мартына билгеләнгән) кабул ителә.

10 нчы сессиядә (1992 нең 18–22 мае, 6–10 июле) ТРның дәүләти һәм коммуналь милкен хосусыйлаштыруның 1992 гә һәм алга таба 1995 кә кадәр исәпләнгән дәүләт программасы, ТРның 1991 гә Респ-ка бюджеты үтәлеше турында хисап раслана; ТРның 1992 гә исәпләнгән бюджет системасы турында; ТР халыкларының телләре; ТРда җир салымының вакытлы күләмен билгеләү турында законнар; 1992 нең 21 мартында булып узган референдум нәтиҗәләреннән чыгып, ТР статусы турында ТР дәүләт суверенлыгын тормышка ашыру чаралары турында; 1992 елга ТРда икътисад эшчәнлеге һәм социаль сфера үсеше турындагы фаразларга ачыклык кертү турында; ТР гражданнарын хәрби хезмәткә чакыру тәртибе турында; респ-ка хокук саклау органнарын этаплап ТР карамагына күчерү, 1991 дә валюта тоту; «КамАЗ» АҖнең элекке СССР автомобиль һәм а.х. машиналары төзелеше министрлыгы карамагындагы дәүләт акцияләрен ТР карамагына күчерү, ТР ЮСның ТР халкын социаль яклау турындагы карарын тормышка ашыруның барышы турында; дәүләт милке чикләрен билгеләү һәм аны хосусыйлаштыру барышында ТРның мөлкәти хокукларын тәэмин итү турында карарлар кабул ителә; ТР Конституциясенә, ТР МК структурасына үзгәрешләр кертелә; ТР һәм Удмурт Респ-касы арасындагы дуслык һәм хезмәттәшлек турындагы Шартнамә раслана; ТР ЮСның халык мәгарифе, фән һәм тәрбия мәсьәләләре буенча даими комиссиясе эше турында хисап тыңлана; ТР Югары арбитраж мәхкәмәсе сайлана.

11 нче сессиядә (1992 нең 28 сент.–2 окт.) ТРның ТР ЮС һәм ТР Президенты тарафыннан кабул ителгән законнарын һ.б. актларны бастырып чыгару һәм кулланылышка кертү тәртибе турында Закон; ТРны күпләп юк итү коралларыннан азат зона буларак игълан итү турында карар кабул ителә.

12 нче сессиядә (1992 нең 28 окт.–6 нояб.) ТР Конституциясе (Төп Закон), ТР Конституциясе Көне турында закон кабул ителә.

13 нче сессиядә (1992 нең 30 нояб.) ТР Конституциясен гамәлгә кертү тәртибе турында Закон кабул ителә.

14 нче сессиядә (1992 нең 21–25 дек., 1993 нең 1–5 марты), 1992–95 елларга ТРда Дәүләт комплекслы җинаятьчелек б-н көрәш программасы раслана; ТР Конституция мәхкәмәсе, ТР Югары арбитраж мәхкәмәсе, дәүләт яшьләр сәясәте, коллектив шартнамәләр һәм килешүләр, җир асты байлыклары, 1993 кә ТРның бюджет системасы турында законнар; ТРда коммуналь милекнең объектлар составы турында; 1993 тә нефть табу күләме һәм аны экспортка чыгару турында; ТР гражданнарының хәрби бурычы һәм хәрби хезмәте турында; ТР ЮС эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру чаралары турында; мәҗбүри мед. иминиятләштерүгә взносларының иминиятләштерү тарифлары турында карарлар кабул ителә; җир өчен түләү, ТР юл фонды турындагы законнарга; ТРны күпләп юк итү коралларыннан азат зона буларак игълан итү турындагы карарга үзгәрешләр кертелә; тузган торакны бетерү һәм аз керемле гаиләләргә торак төзү өчен процентсыз ссудалар бүлеп бирү мәсьәләсе буенча ТР ЮС карарының үтәлеше турында ТР Хөкүмәте хисабы тыңлана; ТР һәм Мари Респ-касы арасында дуслык һәм хезмәттәшлек турында Шартнамә раслана; ТР МК структурасына һәм составына үзгәрешләр кертелә.

15 нче сессиядә (1993 нең 22–24 марты) ТР халкын адреслы социаль яклау Программасы раслана; хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында; акцизлар турында законнар; ТРда хосусыйлаштыруның барышы һәм исемле хосусыйлаштыру кертемнәре системасын гамәлгә кертү турында; хезмәт өчен түләүнең минималь күләмен исәпкә алып, салымнар һәм башка түләүләрне исәпләп чыгару, җыю тәртибе турында карарлар кабул ителә.

16 нчы сессиядә (1993 нең 17–25 мае) Юл хәрәкәте кагыйдәләрен, транспорт чарала-

рын эксплуатацияләү һәм саклау, юл-урам челтәрен һәм хәрәкәт оештыруның техник чараларын тәртиптә тоту кагыйдәләрен бозган өчен адм. җаваплылык, җәмәгать тәртибен һәм идарә итү тәртибен бозган өчен адм. җаваплылык, утлы корал, газ коралы, сугыш кирәк-яраклары һәм аэрозольләр б-н эш итү, аларны саклау һәм куллану кагыйдәләрен бозган өчен адм. җаваплылык, янгын куркынычсызлыгы турында; дәүләти һәм коммуналь милекне тәшкил иткән һәртөрле мөлкәт, акча һәм кыйммәтле кәгазьләрнең сакланышына кагылышлы тәртип бозулар өчен адм. җаваплылык турында; җинаятьчелек б-н көрәштә гадәттән тыш чаралар куллану турында законнар; РФнең яңа Конституциясе проектларына мөнәсәбәт турында; «КамАЗ» АҖнең двигательләр з-дындагы янгын нәтиҗәләрен бетерү чаралары турында; 1993 нең 2 нче кварталында мәҗбүри мед. иминиятләштерүгә взносларының иминиятләштерү тарифлары турында карарлар кабул ителә; ТРда тузган торакны бетерүнең комплекслы программасы раслана.

17 нче сессиядә (1993 нең 12–15 июле) 1992 гә ТРның Респ-ка бюджеты үтәлеше турында хисап; ТР Дәүләт гимнының муз. редакциясе раслана; ТРда кулланучылар кооперациясе, ТРда вет. эше, ТРда торак фондын хосусыйлаштыру, ТРда хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында законнар; ТР терр-ясендә эш бирүче тарафыннан РФ ЮСның 1992 ел 24 декабрь карары б-н расланган хезмәт вазифаларын башкару б-н бәйле рәвештә гариплеккә, һөнәри авыруга дучар булган яки сәламәтлекләренә башкача зыян килгән эшчеләргә килгән зыянны түләтү кагыйдәләрен куллану тәртибе турында; дарулар сатып алу өчен ТР гражданнарын мәҗбүри мед. иминиятләштерүгә Фонды акчаларын куллану турында карарлар кабул ителә; җир өчен түләү, ТРда бәйрәм һәм истәлекле көннәр, җинаятьчелек б-н көрәштә гадәттән тыш чаралар куллану турындагы законнарга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелә; ТР Президентының яңа сәяси шартларда РФ б-н ике арада сөйләшүләр алып барылу турындагы хәбәре тыңлана, район, шәһәр мәхкәмәләре судьялары, ТР Югары мәхкәмә судьялары һәм халык утырышчылары сайлана.

18 нче сессиядә (1993 нең 18–20 окт., 24–26 нояб., 6 дек.) ТРдагы социаль-сәяси вазгыять турында ТР Президенты доклады тыңлана; яшьләр турында; уку-укыту мәсьәләләре; мед. иминиятләштерүгә турында; хезмәт өчен түләүнең минималь күләме, минималь хезмәт хакы, ТРда яшәү минимумы; 1993 елга ТРда бюджет системасын ачыклау турында законнар; РФ Конституциясе проекты турында; ТР гражданнарының хәрби хезмәт үтәве турында карарлар кабул ителә; җинаятьчелек б-н көрәштә гадәттән тыш чаралар куллану турындагы Законга; ТР халкын адреслы социаль яклау Программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелә.

19 нчы сессиядә (1994 нең 7–9 февр., 18–21 апр.) ТРдагы сәяси һәм социаль-икътисади вазгыять турында ТР Президенты доклады тыңлана һәм хуплана; 1993 тә ТРның Респ-ка бюджеты үтәлеше турында хисап; терр. хастаханә кассасы; Респ-ка хастаханә кассасы һәм аның идарә составы турында нигезләмәләр раслана; ТРда минималь хезмәт хакы күләме, дәүләт хезмәте, җир турындагы законнарны бозган өчен адм. җаваплылык; 1994 нең 1 нче яртыеллыгына ТРның Халыкны эш б-н тәэмин итү дәүләт фонды взносларының иминиятләштерү тарифлары турында; 1994 кә ТРның бюджет системасы турында законнар кабул ителә.

20 нче сессиядә (1994 нең 6–8 июне) ТРда минималь куллану бюджеты турында; ТРдагы социаль-икътисади вазгыять б-н бәйле рәвештә, ТР Президентының өстәмә вәкаләтләре турында законнар; ТР икътисадын тотрыклыландыру буенча иң мөһим чаралар турында карар кабул ителә; ТР халкын адреслы социаль яклау Программасына, минималь хезмәт хакы турында, җинаятьчелек б-н көрәштә гадәттән тыш чаралар куллану турындагы законнарга; ТР МК составына үзгәрешләр кертелә.

21 нче сессиядә (1994 нең 18–21 июле) ТРның ТР халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программасы, 1994 кә ТРның Респ-ка бюджеты үтәлешенең барышы турында хисап раслана; ТР дәүләт хакимиятенең вәкиллекле һәм башкарма органнарын реформалаштыру концепциясе хуплана; ТРның Урман кодексы, ТРда чит ил инвестицияләре турында; «Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» яки «Японияне җиңгән өчен» медальләре б-н бүләкләнгән ТР гражданнарына өстәмә ташламалар һәм социаль гарантияләр турында законнар кабул ителә.

22 нче сессиядә (1994 нең 10–13 окт., 23–30 нояб.) ТР дәүләт хакимиятенең вәкиллекле һәм башкарма органнарын реформалаштыру б-н бәйле рәвештә — ТР Конституциясенә, 1994 кә ТРның бюджет системасы турындагы Законга, 1993–95 кә ТРда җинаятьчелек б-н көрәшнең Дәүләт комплекслы программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелә; ТР халык депутатларын сайлау турында; дәүләт хакимияте һәм идарәнең җирле органнары; хакимиятнең җирле вәкиллекле органнарын сайлау; җирле үзидарә турында законнар кабул ителә.

23 нче сессиядә (1995 нең 16–18 гыйн.) ТР халык депутатларын сайлау буенча Үзәк сайлау комиссиясе турында Нигезләмә раслана; профсоюзлар, минималь хезмәт хакы күләме, 1995 нең 1 нче яртыеллыгына ТРның Халыкны эш б-н тәэмин итү дәүләт фонды взносларының иминиятләштерү тарифлары турында законнар; ТР җирле үзидарә органнарына сайлаулар билгеләү турында карар кабул ителә.

1995 тә респ-када хакимиятнең вәкиллекле һәм башкарма органнарын реформалаштыру нәтиҗәсендә ТР ЮС Татарстан Республикасы Дәүләт Советы итеп үзгәртелә.

Чыг.: Конституция (Основной Закон) Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. К., 1937; Конституция (Основной Закон) Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. К., 1978; Конституция Республики Татарстан. К., 1992; Татарская АССР. Верховный Совет 1–11-го созывов: Стенографические отчёты. К., 1938–89.

*Әд.:* Х а ф и з о в Ш.Ш. Развитие советской государственности татарского народа. К., 1966; К а р и м о в А.М. Высшие органы государственной власти автономной республики: По материалам Татарской АССР. К., 1970; ш у л у к. Компетенция высших органов власти автономной республики: По материалам Татарской АССР. 1973; Я г у д и н Ш.Ш. Автономная Советская Социалистическая Республика. К., 1979; ш у л у к. Верховный Совет автономной республики. К., 1985.

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ЮСТИ́ЦИЯ МИНИ́СТРЛЫГЫ**. Тарихы Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна советының 1917 ел 16 ноябрь карары һәм ХКСның «Мәхкәмә турында» 1 нче номерлы 1917 ел 22 ноябрь Декреты нигезендә оештырылган губерна советы юстиция бүлегеннән башлана. Бүлек Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна советы гомуми җыелышының 1918 ел 26 февраль карары нигезендә Казан Совет Эшче-Крәстиян Респ-касының Юстиция комис-ты итеп үзгәртеп оештырыла (шул ук елның 5 мартында ачыла); Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советы Казан губерна башкарма ком-тының 1918 ел 16 май карары һәм Казан губернасы ХКСның 1918 ел 3 июнь карары б-н — Казан губерна Юстиция комис-ты, Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы Казан губерна башкарма ком-тының 1918 ел 15 октябрь карары б-н — губерна башкарма ком-тының юстиция бүлеге, РСФСР БҮБК һәм ХКСның 1920 ел 27 май Декреты һәм ТАССР ҮБКның 1920 ел 28 сентябрь карары б-н ТАССР Юстиция халык комис-ты итеп үзгәртелә. Халык комис-ты хөкем эшләре, дәүләт мәнфәгатьләрен хокукый яктан яклау һәм саклау эшләре б-н идарә итә; законнарның, үзәк һәм җирле хакимият күрсәтмәләренең үтәлешенә күзәтчелек итә; законнарга аңлатма бирә һәм җирле законнар җыелмасын системага сала; хөкем итү вәкаләтләре булган учреждениеләр, иректән мәхрүм итү урыннары эшчәнлегенә күзәтчелек итә; халыкка хокукый ярдәм күрсәтүне оештыра; хезмәт ияләрен хокукый яктан агартуга булышлык итә. Аның составына гомуми, мәхкәмә корылышы һәм мәхкәмә эшләрен башкару, мәхкәмә контроле, мәхкәмә тикшерүе, мәхкәмә статистикасы, консультация, хуҗалык, чиркәүне дәүләттән аеру, төзәтү-тәрбия, нотариаль бүлекләр керә. Халык комис-ты карамагында мәхкәмә оешмалары, тикшерү органнары, адвокатура, нотариат, ТАССР прокуратурасы (1936 га кадәр), Иректән мәхрүм итү урыннары баш идарәсе (1930–34) була. БҮБКга (1937гә кадәр) , ТАССР ҮБКна (1938гә кадәр), ТАССР ХКСна һәм РСФСРның шул исемдәге Халык комис-тына буйсына.

ТАССР Юстиция халык комис-ты ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы нигезендә ТАССР Юстиция министрлыгы итеп үзгәртелә, РСФСР ЮС Президиумының 1957 ел 11 апрель Указы һәм ТАССРның 1958 ел 22 февраль Законы нигезендә гамәлдән чыгарыла (вазифалары ТАССР Югары мәхкәмәсенә тапшырыла), ТАССР ЮС Пре-

зидиумының 1971 ел 4 февраль Указы б-н ТАССР (1990 нан — ТССР, 1992 дән — ТР) Юстиция министрлыгы буларак кабат торгызыла. Министрлык юстиция учреждениеләрендә дәүләт сәясәтен үткәрүне тәэмин итә. Үз эченә исәп-хисап һәм ревизия эшләре; закон проектлары эшләү; ТР норматив хокук актларының бердәм банкы; хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары, җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру бүлекләрен; респ-ка норматив хокук актларына дәүләт теркәве үткәрү; капиталь ремонт һәм биналарны карау; кадрлар секторларын ала. Җәмәгать судьялары һәм 2008 гә кадәр дәүләт нотариаты министрлык карамагында була. ТР Президентына, ТР МКна (1991гә кадәр — ТАССР МС) һәм РФнең шундый ук министрлыгына буйсына.

Халык комиссарлары һәм министрлар: А.Н.Нехотяев (1920–21), Г.Б.Баһаветдинов (1921–26), Х.Р.Палютин (1926–28), Ш.Х.Башкиров (1928–29), В.Н.Филиппов (1929–34), М.У.Усманов (1934–37), А.М.Шмаков (1937–38), И.В.Корнев (1938–40), М.С.Якупов (1941–46), Ш.Ш.Вәлиев (1946–50), Я.Н.Насыйбуллин (1950–57), Ә.Г.Таҗетдинов (1971–87), А.М.Салабаев (1987–2004), М.М.Курманов (2004–13), Л.Ю.Глухова (2013 тән). *Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ЯЗУЧЫЛА́Р БЕРЛЕГЕ́**, язучыларның профессиональ, иҗади, иҗтимагый оешмасы. ТР Я.б. әгъзалары — прозаиклар, шагыйрьләр, драматурглар, тәнкыйтьчеләр, әдәбият галимнәре, матур әдәбият тәрҗемәчеләре. Респ-ка язучыларын берләштерү, иҗади эшчәнлекләрендә ярдәм итү, гражданлык, сәяси, икътисади һәм социаль хокукларын, дәрәҗәләрен яклау өчен 1934 елда (25–29 июльдә) ТАССР язучыларының 1 нче съездында оештырыла. ТР Я.б. эшчәнлегенең мөһим юнәлешләреннән берсе — татар халкының рухи мирасын пропагандалау. Иң югары органы — ТР язучыларының съезды (4 елга бер тапкыр). Анда съездлар арасында эшли торган идарә, аның рәисе, поэзия, проза һәм публицистика, драматургия, балалар әдәбияты, әдәби тәнкыйть, әдәби тәрҗемә һәм рус әдәбияты секцияләренең җитәкчеләре сайлана. Совет чоры тоталитар режимы шартларында язучылар берлекләре еш кына язучыларның иҗади эзләнүләрен контрольдә тотучы, аларга билгеле бер идеологик өлге һәм таләпләр көчләп тагучы орган функцияләрен дә үти. Төрле елларда идарә җитәкчеләре: К.Нәҗми (1934–37), Л.Гыйльми (1937), И.Вахитов (1938–39), М.Җәлил (1939–42), Т.Гыйззәт (1942–44), Ә.Ерикәй (1945–50), Г.Гобәй (1950–53), Г.Бәширов (1953–58), А.Шамов (1958–61), М.Әмир (1937, 1961–68), И.Гази (1968–71), З.Нури (1971–74), Г.Ахунов (1974–84), Т.Миңнуллин (1984–89), Р.Мөхәммәдиев (1989–99), Ф.Галимуллин (1999–2005), И.Ибраһимов (2005–12), Р.Корбанов (2012–16), Д.Салихов (2016 дан). Чаллы һәм Әлмәт шәһәрләрендә төбәк бүлекләре эшли. 2015 нең 1 гыйнварына 327 язучы әгъза булып тора.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ЯЗУЧЫЛА́Р БЕРЛЕГЕНЕ́Ң Г.ИСХАКЫ́Й ИСЕМЕНДӘГЕ́ БҮЛӘГЕ́**, татар халкының рухи мәдәниятенә өлеш керткән өчен тапшырыла торган бүләк. 1991 елда ТР Язучылар берлеге һәм «Туган як» иҗтимагый оешмасы тарафыннан гамәлгә кертелә. Ел саен күренекле әдәбият һәм сәнгать әсәрләре, әдәби-теоретик һәм әдәби-тарихи хезмәтләр, татар әдәбияты классикларының иң яхшы әсәрләре, ш.у. милләтнең рухи байлыгын үстерүгә өлеш керткән һәм актив иҗтимагый-сәяси эшчәнлек алып барган өчен бирелә. 2016 елга 37 лауреат исәпләнә.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ЯЗУЧЫЛАРЫНЫ́Ң ӘДӘБИ́ ФОНДЫ́**, язучыларның иҗтимагый оешмасы. СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге буларак СССР язучыларының 1нче съезды карары нигезендә 1934 елның августында оеша. СССР таркалу сәбәпле, 1992 дә ябыла. 1993 тә яңадан ачылганнан соң, Халыкара әдәби фонд (Мәскәү) составында эшли башлый. Максаты – язучыларга матди ярдәм күрсәтү, аларның иҗади, китап бастыру эшчәнлегенә ярдәм итү, халыкара элемтәләрне үстерү. 1992 гә кадәр фонд бюджеты нәшриятлардан, тамаша учреждениеләреннән (китап бастырудан; пьесалар куюдан һ.б.) килгән акчадан формалаша. Акчалар язучыларның тормыш шартларын яхшыртуга, иҗат йортлары төзүгә, иҗади командировкалар, курслар, семинарлар оештыруга, ярдәмгә мохтаҗ язучыларга ссуда һәм пособие бирүгә тотыла. 1993 тән соң фонд спонсорлар ярдәменә яши. Фондның җитәкчеләре: З.С.Сәмитов (1934–37), Ә.Ә.Исхак (1937–42), З.У.Якупова (1942–46), Г.-Х.Г.Садрый (1946–55), С.С.Сафиуллин (1955–64), С.С.Хәсән (1964–65), М.Г.Шәрифуллин (1965–67), Л.Х.Хәмидуллин (1967–83), Ә.Х.Гадел (1983–84), Л.Л.Лерон (1984–86), Ренат Вәлиев (1986–88), Ш.С.Мостафин (1988–92), Р.Х.Корбанов (1992–94), М.Ә.Шиһапов (1994–96), Д.Х.Салихов (1996–2010), Л.Л.Лерон (2010).

*Л.Х.Хәмидуллин.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ЯШЬЛӘ́Р ЭШЛӘРЕ́ ҺӘМ СПОРТ МИНИ́СТРЛЫГЫ**. ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май карары нигезендә *Татарстан Республикасының Балалар һәм яшьләр эшләре дәүләт комитеты* һәм *Татарстан Республикасының Физик культура, спорт һәм туризм дәүләт комитеты* җирлегендә ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы буларак оештырыла, ТР Дәүләт Советының 2005 ел 29 апрель карары б-н ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы итеп үзгәртелә, ТР Дәүләт Советының 2014 ел 20 март карары б-н хәзерге исемдә. Физик культура, спорт, яшьләр сәясәте һәм 2014 елга кадәр туризм өлкәсендә дәүләт җитәкчелеген гамәлгә ашыра. Элек үз эченә оештыру эшләре, бюджетны планлаштыру һәм үстерү, мәгълүмат-аналитика һәм фәнни эшләр, массакүләм физкультура-сәламәтләндерү эшләре, спорт төрләрен үстерү, балалар һәм яшьләр оешмалары б-н эшләү, өстәмә белем бирү һәм социаль программалар, туризмны үстерү, туристлык эшчәнлегенә дәүләт көйләве һәм аны оештыру бүлекләрен һәм гомуми бүлекне; төбәкара һәм халыкара хезмәттәшлек, спорт һәм үзешчән туризм, дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре, эшләр башкару һәм контроль, хокук секторларын; 2014 елдан — массакүләм физкультура-сәламәтләндерү эшләре; спорт төрләрен үстерү; халыкара эшчәнлек һәм мәгълүматлаштыру-аналитика тәэминаты; фаразлау, бюджетны планлаштыру һәм күзәтчелек итү; программалар үсеше һәм аларны тормышка ашыру; дәүләт заказы, балалар һәм яшьләр оешмалары б-н эшләү; өстәмә белем бирү һәм социаль программалар; оештыру эшләре; эшләр башкару һәм күзәтчелек итү; гомуми бүлекләрне; бухгалтерияне; хокук секторын ала. Министрлык системасында яшьләр эшләре юнәлешендәге һәм спорт профилендәге 39 учреждение бар. ТР Президентына, ТР МКна буйсына. Министрлары: М.М.Бариев (2001–10), Р.Т.Борһанов (2010–14), В.А.Леонов (2014 тән) .

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНДА БӘЙРӘ́М КӨННӘРЕ́**. Закон б-н билгеләнә, күренекле вакыйгаларга, традицион даталарга, билгеле бер һөнәр тармагын һәм анда эшләүчеләрне ихтирам итүгә һ.б. га багышлана. ТРның 1992 ел 19 февраль һәм 2003 ел 3 сентябрь Законы нигезендә билгеләнгән ял көннәре: 30 август — ТР көне (Республика көне); 6 ноябрь — ТР Конституциясе көне; Корбан бәйрәме; Сабан туе татар халык бәйрәме һәм «*Каравон*» рус фольклор бәйрәме билгеләп үтелә (аларны үткәрү вакыты ел саен ТР Президенты Указы б-н билгеләнә), ш.у. 1–5 гыйнвар — Яңа ел бәйрәме; 7 гыйнвар — Гайсә туган көн; 23 февраль — Ватанны саклаучылар көне; 8 март — Халыкара хатын-кызлар көне; 1 Май — Яз һәм хезмәт бәйрәме; 9 май — Бөек Ватан сугышында Җиңү бәйрәме; 12 июнь — Россия бәйсезлеге көне; 4 ноябрь — Халык бердәмлеге көне, ш.у. Ураза һәм Корбан бәйрәмнәре.

**«ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНДА ҖИРЛЕ́ ҮЗИДАРӘНЕ́ ҮСТЕРҮДӘГЕ́ КАЗАНЫШЛА́Р ӨЧЕ́Н» МЕДАЛЕ́**, ТРның дәүләт бүләге. ТР ның 2010 ел 31 декабрь Законы б-н гамәлгә кертелә. Җирле үзидарәне формалаштыру һәм үстерү, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру, җирле мәсьәләләрне халык мәнфәгатьләреннән чыгып, тарихи һәм башка төр җирле традицияләрне исәпкә алып хәл итүдә казанышларга ирешкән граждannар өчен булдырыла. Медаль б-н ТР Президенты бүләкли. ТР Президентының 2011 ел 22 август Указы нигезендә медаль көмештән коелган, ике ягыннан да кабарынкы каймалы, 32 *мм* диаметрлы түгәрәк тәшкил итә. Алгы ягында схематик рәвештә муниципаль районнар һәм шәһәр округларының чикләре төшерелгән, алтынсу төстәге Татарстан картасы урнаштырылган. Медаль әйләнәсен аскы өлештә кисешүче ике лавр ботагы сурәте каймалап тора; өске өлештә — ТР Дәүләт гербы. Медальнең арткы ягында, үзәктә — тәртип саны, әйләнә буйлап өске якта — «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерү-

дәге казанышлары өчен», аскы якта «За заслуги в развитии местного самоуправления» дигән сүзләр. Медаль алтынсу-ак-яшел-кызыл төстәге муар тасма тарттырылган бишпочмаклы колодкага тоташа. Тасманың киңлеге — 20 *мм*, ак буйның киңлеге 2 *мм*, яшел һәм кызыл буйларның киңлеге — 9 *мм*.

2015 нең 1 гыйнварына 201 кеше бүләкләнә.



Татар радиосында радиоспектакль яздыру. Казан. 1930 еллар.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНДА РАДИОТАПШЫРУЛА́Р**. Казан радиодулкыннар кабул итү станциясе 1918 елның 20 мартыннан эшләп килә. Ярты елдан соң радиостанцияләр Тәтеш, Спас, Бөгелмә, Минзәлә, Чистай һ.б. шәһәрләрдә җәелдереп җибәрелә. 1921 нең октябренә ТАССРда 17 радиостанция була, шулар респ-ка терр-ясенең күп өлешен тәэмин итә. Радиотелеграф оешмаларының икенче базасы респ-ка радиосы үсешендә мөһим роль уйный. Аның ярдәмендә Казанда беренче тапкыр үткәргечле радио барлыкка килә. Казанда А.Т.Углов лаб-ясендә әзерләнгән рупорлар В.И.Ленин күрсәтмәсе б-н Мәскәү мәйданнарына куела. Радиотапшырулар үсешенә 1928 ел башында ВКП(б)ның 6 нчы конференциясе делегатлары каршында респ-каны радиолаштыру тәкъдиме б-н чыккан Ш.Х.*Усманов* зур өлеш кертә. Аның актив катнашы б-н 1927 нең ноябрендә 545 *м* лы дулкында — татар һәм рус, 1933 тә — чуаш, 1958 дә удмурт телләрендә эшли башлаган Казан РВ-27 радиотапшырулар станциясе төзелә. Радиотөзелеш мәсьәләләре б-н башта Тамаша пр-тиеләренең Татарстан идарәсе каршындагы радиомонтаж бюросы (директоры — Ш.Х.Усманов) шөгыльләнә. 1928 дән – җитәкчелек Почта һәм телеграф халык комис-ты вәкиле каршындагы Радиосовет һәм Казан радиоүзәгенә, 1932 дән ТАССР Халык комиссарлары Советы каршындагы Татарстан өлкә радиотапшырулар ком-тына күчә. 1924 тә Казанда радиосөючеләргә радиоалгыч җайланмалар әзерләү һәм урнаштыруда ярдәм итәргә тиешле Радио дуслары җәмгыяте оештырыла. 1930 да ТАССР да — 15, 1935 тә — 41, 1948 дә 151 радиоузел эшли. 1930 елларда радиода әдәби тапшырулар мөхәррире — Х.Туфан, музыка мөхәррире – К.Тумашева, музыка бүлегендә С.Сәйдәшев, З.Әлмиев, Ю.Виноградов, С.Алиев, Җ.Фәйзи, А.Ключарёв һ.б. эшли. Радиоком-т каршында проф. башкаручылар коллективлары оештырыла, алар арасында иң атаклысы С.Сәйдәшев оештырган Кече симф. оркестр була. Танылган артистлар Г.Сөләйманова, М.Рахманкулова, М.Мутин, Е.Жилина, И.Самборская, М.Яушев һ.б. эшкә җәлеп ителә. Һәр көнне диярлек микрофон каршында В.Суслин җитәкчелегендәге халык музыка уен кораллары оркестры чыгыш ясый. Татар муз. культурасында 1933 тә радио тыңлаучылар хорыннан үсеп чыккан проф. хор барлыкка килү яңа күренеш була. Радионың З.Әхмәтова җитәкчелегендәге хор коллективы респ-када хор б-н башкару үсешенә этәргеч була. 1938 дә Зеленодольск һәм Чистай шәһәрләреннән үзешчән сәнгать коллективларының концертлары трансляцияләнә. 1963 тә Казанда яңа радио йорты төзелә (1970 тә аның лампалы җайланмасын транзисторлыга алыштыралар). 1962 дә стереоязма һәм стереотапшырулар гамәлгә керә башлый. ТАССР терр-ясендә Казанда – озын ешлыктагы РВ-84 һәм РВ-75 кә өстәмә рәвештә УКВ ЧМ-1, УКВ ЧМ-2, УКВ ЧМ-3, Чаллы, Түбән Кама, Лениногорск шәһәрләрендә, Биләр авылында УКВ ЧМ-1, УКВ ЧМ-2 урнаштырыла, бу исә тапшыруларны өч программада алып барырга ярдәм итә. Әлеге радиостанцияләр стереовариантта Бөтенсоюз программасын (Радио-1), «Маяк» (Радио-11), Өченче союз программасын (Радио-111), Татарстан радиосы программасын, «Маяк»ны трансляцияли. Татарстан радиотапшырулары Мәскәү, Пермь, Самара өлкәләренә, 1998 нең 1 нче августыннан Иркутск, Кемерово, Новосибирск, Омск, Төмән өлкәләренә, Красноярск краена (Иркутск һәм Төмән юнәлешләре), Ленинград, Мәскәү өлкәләренә, Башкортстанга, Мордва Респ-касына (Ленинград юнәлеше) трансляцияләнә.

Хәзерге вакытта ТРда 89 радиоканал эшли, көн саен эфирга татарча һәм русча 150 радиотапшыру чыга. *«Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе* РФ терр-ясендә тәүлек буе тапшырулар алып бара (аның сигналлары Белоруссия, Украина, Болгария, Финляндия, Латвия, Литва, Румыниядә кабул ителә), төрле яштьтәге тыңлаучылар өчен татар телендә мәгълүмати, муз., аналитик, әдәби программалар трансляцияли; радиотапшырулар күләме аена 580 сәг. тәшкил итә. «Татарстан» радиокомпаниясе тапшыруларының гомуми күләме – елына 1630 *сәг.* (аена 136 *сәг.*); 65% ы — татар телендә. ТР терр-ясендә татар телендә 6 иҗтимагый-сәяси һәм 20 әдәби-нәфис, муз., балалар программалары әзерләнә һәм трансляцияләнә. «Татарстан» ДТРКнең кыска дулкыннарында РФнең Үзәк һәм Европа өлешендә, Себердә «Татарстан дулкынында» көндәлек программасы трансляцияләнә. Эфир вакытының атналык күләме 2 *сәг.* 20 *мин.*, аена 9 *сәг.* 20 *мин.*, «Бөтенроссия дәүләт телерадиокомпаниясе» Федераль ДУП ф-лы *«Татарстан» дәүләт телерадиотапшырулар компаниясе* милли тапшырулар хезмәте тарафыннан татар телендә әдәби-муз., мәдәни-агарту һәм рухи-әхлакый эчтәлектәге 7 радиопрограмма әзерләнә. «Татарлар», «Идел белән Урал арасында», «Иртәнге нур», «Тел күрке – сүз» һ.б. программалар аеруча популярлык казана.

*Әд.:* Печать, телевидение и радиовещание Татарии. 1917–1980. К., 1981; Тыңлагыз, Казан сөйли! — Слушайте, говорит Казань! 1927–1997. К., 1998. *Р.А.Айнетдинов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНДА САНИТАРИ́Я-ЭПИДЕМИОЛО́ГИЯ ХЕЗМӘТЕ́** (дәүләт сан.-эпид. күзәтчелеге), дәүләт учреждениеләре системасы; халык сәламәтлеген әйләнә-тирә мохитнең зарарлы тәэсиреннән саклау, хезмәт һәм көнкүреш сан.-гигиена шартларын яхшырту, ил терр-ясендә эпидемиологик иминлек булдыруга юнәлдерелгән сан.-саклык чаралары эшләү һәм уздыру б-н шөгыльләнә. Рев-циягә кадәрге Россиядә бердәм сан.-эпид. хезмәте булмый. Россия терр-ясендә сан.-эпид. күзәтчелеге РСФСР ХКСның «Республика санитария органнары турында» 1922 елда кабул ителгән Декреты нигезендә төзелә. Шул ук елда 13 табибне берләштергән ТАССР сан.-эпид. хезмәте алдына Гражданнар сугышының бер нәтиҗәсе буларак каралган йогышлы авырулардан арыну бурычы куела. 1921 елда респ-када 3 мең — чәчәк б-н, 90 мең — тимгелле тиф, 14 мең — кайтма тиф, 7 меңнән артык корсак тифы б-н авыручы булуы ачыклана; ваба йоктырган 12 меңнән артык кешенең 41% ы вафат була. Сан.-эпид. чаралары күрелү нәтиҗәсендә ваба эпидемиясе таралуга чик куела. 1930 га паразитар тиф төрләре таралышын киметү бурычы үтәлә: тимгелле тиф б-н авыру очраклары — 187, кайтма тиф б-н авыру очраклары 396 тапкырга кими; бизгәк (малярия), дифтерия, полиомиелит, столбняк, түләмә, бруцеллёз, тилерү авыруы, трахома йоктыруның аерым очраклары гына теркәлә. Йогышлы эчәк авырулары киң таралыш алу сәбәпле, су чыганакларын тазарту, торак пунктлардагы сан.-гигиена торышын яхшырту чаралары күрелә.

1930–38 дә кисәтү күзәтчелегенең башкарма органын ТАССР дәүләт сан. инспекциясе тәшкил итә. 1942 дән пр-тиеләрдә мед. хезмәте күрсәтү б-н яңа төзелгән һәм эреләндерелгән мед. сан. частьлары (МСЧ) шөгыльләнә башлый, аларның вазифаларына

агымдагы һәм кисәтү сан. күзәтчелеге уздыру, йогышлы авыруларны, проф. авырулар һәм травмаларны кисәтү кирә. Сәнәгать пр-тиеләренә мед. хезмәте күрсәтү буенча сан.-эпид. күзәтчелеген оештыручылар, сәнәгатьтәге сан. табибләре (А.Н.Крепышева, Р.Г.Сюняков, М.С.Кузнецова, Т.И.Черанова, Ш.Е.Ошерова, З.Г.Нахабина, А.Ф.Страхова, З.Г.Матвеева һ.б.) зур эш алып бара. 1942 дә, халыкның кар астында кышлаган башакларны җыеп куллануы сәбәпле, кешеләр арасында күпсанлы үлем очракларына китергән (1943 тә — 18,2%) септик ангина тарала. 1944 тә азыктан агуланулар 1943 ел б-н чагыштырганда 1,5 тапкыр артыграк була, әмма үлемнәр күзәтелми. Эпидемияләргә каршы чараларны дөрес оештыру, гомуми мед. һәм сан.-эпид. челтәре табибләренең фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә 1945 кә тулаем авыру очраклары кимүгә йөз тота (сугыш алды елларындагы дәрәҗәдән түбән); авыру йоктырулар кими (корсак тифы б-н — 3, дизентерия б-н — 20, дифтерия б-н — 3 тапкырга); балалар үлеме сугышка кадәрге дәрәҗәдән түбән). Эпидемияләргә каршы һәм сан. таләпләрен үтәүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм уздыру мед. кадрлары җитешмәү сәбәпле катлауланa. 1941–42 дә күп кенә мед. хезмәткәрләре Кызыл Армиягә мобилизацияләнә; кадрлар дефициты эвакуацияләнеп килгән белгечләр хисабына өлешчә тулыландырыла. Йогышлы авырулар б-н көрәшне оештыруда инфекция учакларына ТАССР ХКС вәкилләрен юллауның әһәмияте зур була. Инфекцияләргә чик куюда, сан. һәм эпидемияләр б-н бәйле мәсьәләләрне хәл итүдә Казан мед. ин-ты, Казан ГИДУВы, Казан эпидемиология һәм микробиол. фәнни-тикшеренү ин-ты, Казан вет. ин-ты, Бизгәк (малярия) станциясенең (1935 тә оештырыла) әйдәп баручы белгечләре катнаша. Бактериологик, серологик лаб-яләр эшчәнлеге җәелдерелә, 1942 дә бруцеллёз лаб-ясе ачыла. Сан.-аңлату эшләренә зур игътибар бирелә; рус һәм татар телләрендә брошюралар, плакатлар, листовкалар басыла башлый (җитәкчесе — Ф.Г.Мөхәммәдъяров). Бөек Ватан сугышы ахырына респ-када 94 дәүләт сан. инспекторы һәм 144 сан. инспектор ярдәмчесе исәпләнә, ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы өлкә сан.-эпид. станциясе, 2 — шәһәр (Казанда һәм Зеленодольскида), 37 район сан.-эпид. станциясе оештырыла. 1948 дә эпидемияләргә каршы көрәшүче отряд, һөнәри дезинфекция бүлеге һәм өлкә сан.-эпид. станциясе җирлегендә ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка сан.-эпид. станциясе төзелә (штаты — 75 берәмлек). РСФСР Сәламәтлек саклау министрлыгы карары нигезендә 1955 тә район сан.-эпид. станцияләре үзәк район хастаханәләре б-н берләштерелә. 1964 тә ТАССР сәламәтлек саклау министры М.И.Грачёв башлангычында сан.-эпид. станцияләр дәүләт сан. күзәтчелеге функциясен үтәүче мөстәкыйль оешмага әверелә, алар Татарстан АССРның һәр районында оештырыла. Бактериологик лаб-яләр челтәрен киңәйтүгә, аларның матди-техник базасын ныгытуга игътибар бирелә. 1960 елларда сан. хезмәте белгечләренең тәкъдимнәре Татарстан шәһәрләрен (Әлмәт, Лениногорск, Азнакай, Баулы һ.б.) һәм шәһәр-районнарны төзү-төзекләндерү, нефть амбарларыннан һәм факеллардан арыну, чистарту корылмалары төзү барышында; Куйбышев сусаклагычын төзү б-н бәйле эшләрдә: инженерлык саклау корылмалары торгызганда, каберлекләрне санацияләгәндә, торак пунктларны күчергәндә, урманнарны кискәндә (Казан; Лаеш, Алексеев, Чистай, Балык Бистәсе, Куйбышев р-ннары һ.б.); Түбән Кама, Чаллы шәһәрләрен төзегәндә файдаланыла.

Халык хуҗалыгында радиоактив матдәләр һәм башка ионлаштыручы нур чыганаклары куллануның артуы сәбәпле, 1958 дә Респ-ка сан.-эпид. станциясендә радиология төркеме оештырыла, аннары Респ-ка радиация куркынычсызлыгы үзәге, Әлмәт (1968), Чаллы (1976) сан.-эпид. станцияләре каршында зона радиология төркемнәре, Казан шәһәр сан.-эпид. станциясе каршында радиацион гигиена бүлеге (1991) барлыкка килә.

А.х.н химияләштерү, пестицидлар куллану б-н бәйле рәвештә, азык продуктларында һәм тышкы тирәлектә пестицид калдыклары күләмен билгеләү өчен, Респ-ка сан.-эпид. станциясендә, Казан, Әлмәт, Бөгелмә, Яшел Үзән, Чаллы, Чистай, Лениногорск, Буа шәһәр сан.-эпид. станцияләрендә лаб-яләр төзелә. Лаб-яләрдә ел саен 8,5 меңнән артык тикшерү уздырыла, шуның б-н а.х. продукциясен куллану куркынычсызлыгы гарантияләнә. 1987 дә Казанда электромагнит кырлары һ.б. физик факторлар лаб-ясе төзелә, соңрак ул техник яктан компетентлы һәм бәйсез үзәк статусына ия бүлеккә әверелә. 1980 еллар ахырында Респ-ка сан.-эпид. станциясендә яшәү тирәлегенең кеше организмына тәэсирен төрле яклап өйрәнү өчен бүлек оештырыла, 1993 тә бүлек нигезендә ТР сан.-эпид. күзәтчелеге шәһәр ком-тының Респ-ка мәгълүмат-аналитика үзәге булдырыла. 1990 елларда Казан мед. ун-ты һәм Казан мед. академиясе галимнәренең респ-ка халкы сәламәтлегенә әйләнә-тирә мохит факторлары тәэсирен өйрәнү буенча уртак эшчәнлеге башлана.

1991 дә Татарстан Респ-касының сан.-эпид. күзәтчелеге дәүләт ком-ты оештырыла, шәһәр һәм район сан.-эпид. станцияләре дәүләт сан. күзәтчелеге үзәкләре дип үзгәртелә. Ком-т составында сан.-гигиена, эпид. күзәтчелеге, радиация иминлеге, гигиена сертификациясе һәм лицензияләү, мәгълүмат-аналитика үзәкләре барлыкка килә. 1993 тә ТРда респ-кага кертелә торган продукцияне тикшереп кабул итү өчен Респ-ка гигиена сертификациясе һәм лицензияләү үзәге булдырыла.

1990 елларда тормыш дәрәҗәсенең кинәт төшүе йогышлы авырулар, ш.и. дифтерия, туберкулёз, сифилис, В һәм С вируслы гепатитлар, СПИД, бизгәк (малярия), табигать-төбәк б-н бәйле зооноз инфекцияләр (талпан энцефалиты, бөер синдромлы геморрагик бизгәк) таралуга китерә. 2000 елга респ-када дифтерия б-н авыру очраклары 1966 ел дәрәҗәсенә төшерелә, полиомиелитка каршы иммунизация оештырыла, эпид. иминлек тәэмин итү (СПИДны, венерик авыруларны, кискен эчәк инфекцияләрен һәм зооантропоноз инфекцияләрне кисәтү), вакытсыз үлемнәрне киметү максатыннан кичектергесез чаралар күрүгә юнәлтелгән дәүләт программалары тормышка ашырыла; туберкулёзга каршы көрәш, ТР терр-ясенә аеруча куркыныч йогышлы авырулар үтеп керүдән һәм таралудан саклану буенча махсус респ-ка программалары эшли.

2001 дә ТРның сан.-эпид. күзәтчелеге дәүләт ком-тының эшчәнлеге туктатыла, аның дәвамчысы буларак, «Татарстан Республикасындагы дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеге үзәге» оештырыла. 2005 тә терр. федераль орган — респ-каның шәһәр һәм районнарында 17 терр. бүлеге булган «Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе» төзелә. «Татарстан Республикасындагы дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеге үзәге» җирлегендә максаты Идарә һәм аның бүлекләренең дәүләт күзәтчелеге эшчәнлеген тәэмин итү булган «Татарстан Республикасындагы (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе оештырыла, респ-каның шәһәр һәм районнарында аның ш.у. 17 терр. бүлеге булдырыла.

2014 елда ТРда Идарәгә караган 12 бүлек, Гигиена һәм эпидемиология үзәге (12 ф-лы б-н) эшли; сан.-эпид. хезмәте системасында 1,8 меңнән артык белгеч: 500 дән артык табиб һәм 500 дән артык урта мед. персоналы, ш.и. 4 мед. фән. д-ры һәм 8 мед. фән. канд. хезмәт куя; 4 кеше — «Роспотребнадзор»ның мактаулы хезмәткәре, 18 кеше — сәламәтлек саклау отличнигы, 2 кеше — сан.-эпид. хезмәте отличнигы.

ТАССРның баш сан. инспекторлары: Т.Д.Эпштейн (1937–45), Р.Г.Сюняков (1945–49), Н.А.Немшилова (1949–53), А.Н.Крепышева (1953–55). ТАССРның Дәүләт сан.-эпид. хезмәте җитәкчеләре, ТАССРның баш сан. табибләре: И.М.Штейнбух (1948), Ш.Э.Кумратов (1949–51), М.Ф.Кунаков (1951–52), Е.Э.Зыкова (1952–55), А.И.Черанова (1955–56), И.З.Мөхетдинов (1956–64), А.Д.Сафонова (1964–65), Б.Л.Якобсон (1965–84). Респ-ка сан.-эпид хезмәте б-н 1984–2011 дә — В.В.Морозов, 2011 дән М.А.Патяшина җитәкчелек итә.

*Әд.:* Этапы развития и становления государственной санитарно-эпидемиологической службы Республики Татарстан // Казан. мед. журн. 1999. № 1.

*В.В.Морозов, В.А.Трифонов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНДА ТЕЛЕВИ́ДЕНИЕ ТАПШЫРУЛАРЫ́.** Татарстанда телевидение (ТВ) тарихының башы Казандагы Кече (һәвәскәр) телеүзәк б-н бәйләнгән. Аны оештыруда Казан радиоклубы энтузиастлары катнаша, алар 50 Вт егәрлегендәге телевидение тапшыргычын, егәрлек көчәйткечне һәм телевидение антеннасын коралар. Сынап карау өчен, 4 телевизор кулланыла: берсе кабул итү пульты б-н «Татэнер-

го» бинасына куела, калганнары — Офицерлар йортында, Казан авиация ин-тының радиотехника ф-тында һәм радиоклубта. Кече телеүзәкнең сынау тапшыруы 1954 елда була: телевизорны көйләү өчен сынау таблицасы һәм магнитофон тасмасына язылган музыка трансляцияләнә.

Телеүзәкнең беренче телетапшыруы 1955 нең 27 февралендә, РСФСР ЮСна сайлаулар көнендә була. Кабул итү үзебездә чыккан «КВН-49», «Ленинград-Т2», «Авангард» телевизорларында гамәлгә ашырыла. Әлеге тапшыруны ике сайлау участогында, Казан авиация ин-ты, Казан элемтә техникумында, радиоклуб, Казан ун-ты биналарында һәм Казан радиоһәвәскәрләре йортында карарга мөмкинлек туа. Кече телеүзәкне оештыру һәм җиһазландыруда «Радиоприбор», Казан оптика-механика з-длары, Казан авиация ин-ты, Казан ун-ты, радиотрансляция челтәре дирекциясе белгечләре катнаша. ТАССР МСның «Вакытлыча телеүзәк эше турында» 1955 ел 18 ноябрь карары нигезендә ТАССРның Татарстан Респ-ка элемтә идарәсе «Радиоприбор» з-дыннан телеүзәк өчен җиһазлар алырга һәм аның нормаль файдаланылуы өчен шартлар тудырырга тиеш була. ТАССР Мәдәният министрлыгына даими телетапшыруларны тәэмин итү бурычы куела. 1956 ның 12 февралендә Кече телеүзәкнең тапшырулары Чернышевский урамындагы яңа бинадан башлана. Телеүзәк эшчәнлегенең беренче елында телевизор караучылар игътибарына киножурналлар, фәнни-популяр һәм документаль фильмнар тәкъдим ителә. Тапшырулар чәршәмбе һәм җомга көннәрендә 19.00 *сәг.*тә була. 1957 дә барлык электрон гаммәви мәгълүмат чаралары, ш.и. телевидение тапшырулары Мәдәният министрлыгы карамагыннан чыгарыла һәм ТАССР МС каршында оешкан Радиотапшырулар һәм телевидение ком-тына буйсынуга күчерелә (1958 дән ком-т рәисе итеп М.Ф.*Долгов* билгеләнә). 1958 нең 22 февралендә Кече телеүзәкнең студиядән беренче тапшыруы була, ул Совет Армиясенең 40 еллыгына һәм Кече телеүзәкнең 3 еллыгына багышлана. Телеүзәк каршында 14 кешедән торган сәнгать советы оеша, аның 1 нче төркеменә язучылар Ә.Исхак, Г.Паушкин, Ф.Хөсни, композиторлар Х.Вәлиуллин, А.Ключарёв, музыкант Ә.Хәйретдинов, дирижёр Ә.Абдуллин, актёр һәм режиссёрлар Х.Сәлимҗанов, Ш.Сарымсаков, нәфис тапшырулар баш мөхәррире Г.Хөсәенов, муз. тапшырулар мөхәррире З.Хәйруллина һ.б. керә.

Зур Казан телеүзәге 1959 ның 12 октябрендә эшли башлый (рәсми ачылышы 1959 ның 1 ноябрендә була). Беренче тапшыруда КПССның Казан шәһәр ком-ты, шәһәр башкарма ком-ты, ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение ком-тының әйдәп баручы хезмәткәрләре катнаша. Казан ун-тының студентлар оркестры, Татар опера һәм балет театры артистлары чыгыш ясый. Телепрограмма фильмнар күрсәтү б-н тәмамлана. 1959 ның 3 ноябреннән «Советская Татария» г-тасында телепрограмма басыла




«Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе. Казан

башлый. 1959 да Казан телестудиясендә 116 кеше эшли.

1962 дә Мәскәү–Свердловск магистраль радиореле линиясен төзү тәмамлана, Казан Үзәк телевидение программаларын ретрансляцияләү мөмкинлеге ала (Мәскәүдән беренче тапшыруны казанлылар 1962 нең 16 мартында карый). 1963 тә Лениногорск шәһәрендә атнага 3 тапкыр УТ-33 тибындагы француз тапшыргыч техникасы б-н җиһазландырылган телеүзәк эшли башлый. 1965 тә Казан–Лениногорск радиореле линиясе эксплуатацияләнә, Лениногорскида һәм Чистай р-нында Үзәк телевидениенең 1 нче каналы тапшырулары трансляцияләнә башлый. 1969 да телевидение тапшыруларын Түбән Кама р-нында да карый башлыйлар. 1972 дә Казан телестудиясе тарафыннан тапшыруны алдан яздыру технологиясе үзләштерелә. 1974 тә телестудия ПТС-4 күчмә телестанциясенә ия була (камералары 30 *км* дан тапшыра ала торган 4 камералы 2 «ЛиАЗ» автобусы). 1976 ның ноябрендә студия фонды язмаларын саклау өчен видеотека булдыру турында карар кабул ителә.

1970 еллар башында Татарстанның 80% терр-ясендә телетапшырулар даими кабул ителә. 1973 кә Үзәк телевидениенең 1 нче программасын — ТАССРның 80% халкы, 1 һәм 2 нче программасын 55% ка якыны карый. 1976 да Лениногорск һәм Түбән Кама ретрансляторлары тулы куәтенә эшли, 1977 дә Чистай–Түбән Кама–Чаллы радиореле линиясе өстәлә. Казан ретрансляция телестанциясе Үзәк телевидениенең 3 нче про-



Казан телестудиясендә тапшырулар яздыру. 1970 еллар

граммасын кабул итә башлый. Татарстан телевидениесенең үз тапшыруларының күләме елына 554,2 сәг. тәшкил итә.

СССР Дәүләт телерадиосы планы буенча 1978–80 елларда Татарстан төсле тапшыруга күчәргә тиеш була. 1978 нең июнендә Казанда алга таба Казанның В.В.Куйбышев исем. химия з-дында эшкәртелергә тиешле 35 *мм* лы негатив кинотасмага төсле кинороликлар төшерү буенча тәҗрибә эшләре башлана. 1979 ның башында Казан телеүзәге «Магнолия» ПТС-ЦТ күчмә төсле телевизион тапшырулар җиһазыннан, ПТВС-2ЦТ төсле телевизион видеоязма станциясеннән һәм ПВС-4 күчмә видеоязма станциясеннән файдалана башлый. 1982 нең 5 маенда КПССның Татарстан өлкә ком-ты һәм ТАССР МС тарафыннан «Республика телевидениесе программаларын тулысынча төсле тапшыруга күчерү һәм Татарстан АССРда телевидение тапшыруларын алга таба үстерү турында» карар кабул ителә. Аның нигезендә 1985 кә респ-ка телевидениесенең аппарат-студия комплексы һәм төсле киноматериалларны эшкәртү кинокомплексы реконструкцияләнә, җирле телевидение программасы тулысынча төсле тапшыруга күчә. 1989–90 да Лениногорск–Әлмәт, Лениногорск–Бөгелмә радиореле линиясе сафка баса.

Татарстан телевидение тапшыруларының беренче проф. белгечләре арасында — мөхәррирләр И.Ихсанов, Ф.Борнашева, журналист К.Янгулов, диктор Ә.*Сафиуллина*. Беренче даими «Соңгы хәбәрләр» телетапшыруының башында К.Вәлишев, Н.Ганиев, К.Янгулов тора. Студиянең беренче елларындагы дикторлары А.*Арсланов*, А.*Дубин*, И.Сакаева, Л.Жукова, Л.*Заһидуллина* һ.б. Татарстан телевидение тапшыруларының «йөзе» булып санала. Телевидениенең оешуы һәм үсешендә журналистлар В.Булычёв, М.Шувалова, реж. Г.*Хөсәенов*, операторлар К.Аристов, Е.Афанасьев, Т.Кальюранд, В.Миронов, Э.Сиражетдинов, Э.Юмакулов һ.б. зур роль уйный. 1960 еллар ахырында Казан телестудиясендә мөхәррир булып күренекле кинорежиссёр С.*Говорухин* эшли.

Татар телевидениесенең күп кенә программалары Үзәк телевидениедән трансляцияләнә (беренче шундый программалардан — дикторлар Ә.Сафиуллина, А.Арсланов, А.Дубин, И.Сакаева алып барган «Голубой огонёк» тапшыруы һәм Җ.Фәйзинең «Башмагым» муз. драмасы, реж. В.Мурзина). Бөтенсоюз тиражлавына Казан телестудиясенең «Халык комиссары турында хикәя» («Рассказ о народном комиссаре»), «Девонны буйсындыручылар» («Покорители девона»), «Легенданы тергезү» («Возрождение легенды») һ.б. фильмнары кабул ителә.

1966 да Казан телестудиясе көче б-н татар революционеры М.Вахитов турында беренче тарихи фильм – «Халык комиссары турында хикәят» («Рассказ о народном комиссаре», сценарий авторы һәм реж. И.Үтәгәнов) туа, фильм җирле телестудияләр фестивалендә «Иң яхшы тарихи фильм» дипломы б-н бүләкләнә. 1970 еллар — 1980 еллар башында телестудия берничә тапкыр теле-

фестиваль лауреаты була. «КамАЗ бригадирлары» («Бригадиры КамАЗа»), «Нәҗип Җиһанов музыкасы» («Музыка Назиба Жиганова»), «Башладык» («Пуск») фильмнары төшерелә, тиражлана һәм Үзәк телевидение тапшырулары аша күрсәтелә. 1980 дә немец теленә тәрҗемә ителгән «Татар сувенирлары» («Татарский сувенир») документаль телефильмы һәм «Ләйсән» концерт программасы Лейпциг шәһәрендә (Германия) узган халыкара көзге ярминкәдә күрсәтелә. Казан телестудиясенең беренче нәфис фильмнары арасында — 1,5 сәгатьлек «Ышанасы килә» («Хочу верить», реж. И.Прошкуратов, оператор И.Шәмсетдинов) тасмасы, татар телендәге 20 минутлык «Шомырт чәчәге» (реж. Р.Сакаев, оператор И.Шәмсетдинов) фильмы, татар телендәге «Беренче театр» тулы метражлы фильмы (реж. Р.Сакаев, оператор А.Привин). 1970 тә Фильмнар төшерү баш редакциясе оеша (җитәкчесе — И.Ихсанов), аның беренче эшләре арасында — ТАССРның 50 еллыгына багышланган 5 серияле «Совет Татарстаны» («Советский Татарстан») тарихи-документаль фильмы. 1971–78 дә КамАЗ төзелеше турында документаль фильмнар сериясе чыга. Аларның күбесе Бөтенсоюз алмашу фондына кабул ителә һәм Үзәк телевидениенең 1 нче программасы һәм җирле канал буенча берничә тапкыр күрсәтелә: «КамАЗ башлана» («КамАЗ начинается», 1971); «КамАЗ бригадирлары» («Бригадиры КамАЗа», 1972); «КамАЗ. Сынаулар елы» («КамАЗ. Год испытаний», 1973–74); «КамАЗ коммунистлары» («Коммунисты КамАЗа», 1975) һ.б. тасмалар. 1981 дә Казан телестудиясе документалистлары Р.Рубцова (сценарий авторы), В.Беспалов (реж.) һәм В.Щеглов (оператор) «КамАЗ. Икенче сулыш» («КамАЗ. Второе дыхание») фильмын Ереванда узган 9 нчы Бөтенсоюз телефильмнар фестивалендә тәкъдим итә.

1994 тә *«Татарстан» Дәүләт телерадиотапшырулар компаниясе* студиясендә мәгълүмати программаларны кинотасмадан видеоязмага күчерү гамәлгә ашырыла. 1997 дән эфирга спутник элемтә каналлары буенча алынган видеоматериаллар кулланыла, видеографика һәм компьютер дизайны студияләре файдаланыла башлый. 1997 дә «Бөтен Россия» Бөтенроссия төбәк телекомпанияләре фестивалендә «Татарстан» ДТРК «Вероника» (авторлары Р.Сәхәбетдинова, З.Куртаева) фильмы һәм «Виртауль тәэсирләр» («Виртуальные впечатления») циклыннан «Обломовчылык» («Обломовщина») тапшыруы өчен (авторлары Д.Әхмәтова, А.Долбин, Р.Галиев, М.Залюшев), 1999 да 4 нче «Бөтен Россия» фестивалендә «ТВ дикторы» студиясе — атналык «Ханым» циклы өчен дипломнар б-н бүләкләнә.

1998 дә РФ Президенты карары б-н Бөтенроссия ДТРК һәм 89 төбәк тапшырулары б-н бергә «Татарстан» ДТРК дәүләт электрон массмедиа корпорациясенә керә. Сыйфатлы телевидение тапшыруларына ихтыяҗ үсүгә бәйле рәвештә, Татарстан хөкүмәте тарафыннан яңа нигездә милли-респ-ка телевидениесен оештыру турында карар кабул ителә. 2002 дә *«Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе* оеша. Әлеге компаниягә кергән «Татарстан — Яңа гасыр» («ТНВ») каналы 2002 нең 26 августыннан эшли башлый, татар һәм рус телләрендә тәүлегенә 22 *сәг.* тапшырулар алып бара. «ТНВ» тапшыруларын трансляцияләү өчен 2002 дә Казанда Россиядә 1 нче төбәк космик телеүзәге һәм спутник аша тапшырулар системасы файдаланыла башлый. Спутниклар аша сигнал Россия терр-ясенә, БДБ илләренә, Европа һәм Азиянең шактый өлешенә тарала. Татарстанның барлык терр-ясе ныклы даими кабул итү зонасында; телеканал тапшыруларын ш.у. РФнең күп төбәкләрендә, Казакъстанда, Кытайда, Төркиядә, Балтыйк буе илләрендә, Финляндиядә, Чехиядә карыйлар. «ТНВ» сайтында трансляция (www.tnv.ru) реаль вакыт режимында гамәлгә ашырыла. «ТНВ» ТРда әйдәп баручы телеканал, ТРда заманча телевидениенең йөзе булып тора. Тапшыруның гомуми күләме — аена 600 *сәг.*тән артыграк (яртысы — татар телендә). «ТНВ» тамашачыларга телепрограммаларның тулы спектрын, ш.и. 40 тан артык цикллы үз программа һәм тапшыруларын тәкъдим итә. Корпунктлардагы журналистлар респ-ка халкын татарлар күпләп яшәгән җирләрдәге күренекле кешеләр тормышы һәм торак пунктлар тарихы б-н таныштыра.

Хәзерге вакытта респ-када 73 телеканал теркәлгән, аларның бер өлеше ТР телерадиотапшырулары ассоциациясенә берләшкән. Казанда телеүзәк бар, җирле 7 телеканал (*«Эфир»*, ITV, TM TV, ТНВ, «Мәйдан», «Казань», «Первый городской» һ.б.) эшли.

1991 дә Казанда оешкан «Эфир» компаниясе — ТРда дәүләт телетапшырулар системасыннан бәйсез беренче телекомпания. Аның көндәлек мәгълүмати «Город» программасы Бөтенроссия телевизион конкурсларында берничә тапкыр бүләкләнә. 1990 еллар ахырыннан ТРда — кабельле Телевидение тапшырулары, 2000 еллар уртасыннан спутник аша һәм санлы телевидение тапшырулары актив үсеп китә, халык шулар ярдәмендә РФнең башка төбәкләре каналларына һәм чит ил телекомпанияләре тапшыруларына керү мөмкинлеге ала.

Чыг.: Печать, телевидение и радиовещание Татарии. 1917–1980: Сб. док. и материалов. К., 1981.

*Әд.:* Орлова А.Ф. Время и связь: Очерки по истории связи в ТАССР. К., 1988; Государственная телерадиокомпания «Татарстан». К., 2000; Даутова Р.В. Становление и развитие телевидения Татарстана (вторая половина 1950-х — 1985 гг.). К., 2008.

*Р.В.Даутова.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АНАЛА́Р ҺӘМ БАЛАЛА́Р СӘЛАМӘТЛЕГЕ́Н САКЛА́У ҮЗӘГЕ́**. 1992 елда оештырыла, 2000 нән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка мед.-социаль тикшеренүләр һәм сәламәтлек саклау икътисады үзәге составында була. Эшчәнлегенең төп юнәлешләрен гаиләләрдәге мед.-социаль проблемаларны, Татарстан шәһәрләре һәм авылларында яшүсмерләр сәламәтлеге торышын, хатын-кызлар һәм балалардагы төрле патология очракларында, нәтиҗәлелеге зур булмаган экологик фактор буларак, микроэлементлар алмашын өйрәнү; гаиләле баласыз парлар сәламәтлегендәге тайпылышларны ачыклау һәм репродуктив функцияне тергезү; хатын-кызларда, яңа туган һәм кече яшьтәге балаларда сексуаль-трансмиссив инфекцияләргә диагноз кую; реабилитация комплекслары эшләү тәшкил итә. Өстенлекле юнәлешләр: булачак аналар сәламәтлеген кайгырту, фето-инфантиль (ралгы һәм яңа туган балалар) һәм репродуктив югалтуларны кисәтү, перинаталь ярдәм, белгечләр ярдәмен үстерү, авыруларны вакцина ярдәмендә кисәтү, мәктәп балалары, ш.и. яшүсмерләр сәламәтлеген кайгырту, балаларның тышкы сәбәпләрдән үлү очракларын булдырмау, гаиләләргә психол. ярдәм, организмның какшавына китерүче зарарлы гадәтләрне кисәтү. 2001 елда эшчәнлеге туктала. Җитәкчесе — С.В.Мальцев (1992–2001) Ш.у.к. *Республика балалар клиник хастаханәсе, Балалар санаторийлары.*

*Әд.:* Макаров Ю.В., Макарова Г.А., Еникеева Р.И. К истории становления педиатрической службы в Казани // Казан. мед. журн. 1967. № 5; Мальцев С.В. Охрана здоровья матери и ребёнка в Республике Татарстан // Казан. мед. журн. 2003. № 1.

*Д.Р.Нуретдинова.*

**«ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ А́РМИЯ, АВИА́ЦИЯ ҺӘМ ФЛОТКА́ БУЛЫШЛЫ́К ИТҮ́ ИРЕКЛЕ́ ҖӘМГЫЯТЕ́ (ДОСААФ)» ТӨБӘ́К ИҖТИМАГЫ́Й-ДӘҮЛӘ́Т БЕРЛӘШМӘСЕ́**. Татарстан оборона иҗтимагый оешмаларының: Хәрби фәнни җәмгыять (1921–26), Һава флоты дуслары җәмгыяте (1923–25), Химия оборонасы һәм химия сәнәгате дуслары җәмгыяте (1924–25), Авиация һәм химия сәнәгате дуслары җәмгыяте (1925–27), Оборонага, авиация һәм химия төзелешенә булышлык итү җәмгыяте (ОСОАВИАХИМ, 1927–48), Авиация, флот, армиягә булышлык итү җәмгыяте (1948–51), Армия, авиация һәм флотка булышлык итү ирекле җәмгыяте (ДОСААФ, 1951–91), Россия оборона спорт-техника оешмасы (РОСТО, 1991–2004), Россия оборона спорт-техник оешмасы – РОСТО (ДОСААФ) (2004–08), «ТРның төбәк оборона спорт-техник оешмасы РОСТО (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (2008–12) дәвамчысы. 2013 тән хәзерге исемдә. Максатлары — илнең оборона сәләтен ныгытуга, гражданнарны хәрби-патриотик тәрбияләүгә юнәлтелгән чаралар оештыруга, спортның авиация, техник һәм хәрби-гамәли төрләрен, яшьләрнең техник иҗатын үстерүгә, гражданнарны хәрби-исәп белгечлекләре буенча әзерләүгә, киң таралган техник һөнәрләр буенча кадрлар әзерләүгә ярдәм итү. 1920–30 елларда хәрби хезмәткә чакырылучы яшьләрне хәрби өйрәтүләр хәрби укыту пунктларында (пехота, кавалерия, артиллерия, диңгез, ату буенча) ОСОАВИАХИМ район советларында һәм барлык пр-тие, учреждение, колхоз, совхозларда, «Готов к труду и обороне СССР», «Ворошиловский стрелок», «Ворошиловский всадник», «Моряк», «Готов к ПВХО» кебек комплекслар нормалары тапшыру һәм армия өчен автомотоклубларда, хезмәт этләре асраучы клубларда, кавалерия, ату буенча, планер һ.б. мәктәпләрдә белгечләр әзерләү б-н гамәлгә ашыры-

ла. 1940 елга ОСОАВИАХИМның үзәк советы түбәндәге оешмаларны берләштерә: «А» тибындагы лагерь, кавалерия, автомобиль, хәрби-диңгез, радио һәм ату буенча мәктәпләр, хезмәт этләре өйрәтүчеләр мәктәбе, Казан (2 нче категория) һәм Чистай (4 нче категория) аэроклублары, газдан арындыру отряды, уку-укыту-күгәрченнәр өйрәтү станциясе, сәяси сектор, оешманың 61 шәһәр районнары советы.

Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан ОСОАВИАХИМ оешмалары тарафыннан 36 белгечлек буенча 163685 кеше әзерләнә. Аларның күпчелеген укчы-сугышчылар (154481 кеше), алардан тыш радистлар (1459 кеше), телеграфчылар (887), радиоинструкторлар (45), очучылар, планерчылар, парашютчылар, авиатехниклар (1934), диңгезчеләр (1828), хәрби-диңгез инструкторлары (50), хезмәт этләре йөртүчеләр (30 кеше), һава һөҗүменнән һәм химик һөҗүмнән саклану гаскәрләре сугышчылары (1,9 млн. кеше) тәшкил итә. 1960–80 елларда ДОСААФның Татарстан өлкә оешмасында спортның 20 авиация-техник һәм хәрби-гамәли төре җәелдерелә, 5 дөнья, 18 бөтенсоюз рекорды куела. Иң яхшы спортчылар арасында (дөнья, Европа чемпионатларында катнашучылар һәм медаль алучылар) — К.Головин (судно моделе спорты), В.С.Ермоленко (парашют спорты), Г.Г.Калистратов, О.Клементьев (судно моделе спорты), А.Сильванович (планер спорты), Е.П.Смирнов, А.Г.Смоленцев, В.И.Титлов (авиамодель спорты). 1980 еллар ахырына ДОСААФ оешмасында 4068 беренчел оешма, 54 район, 15 уку-укыту оешмасы, 82 спорт-техник клубы эшли. Матди-техник базаны 29 уку бинасы, 82 хәрби-техник укыту йорты, 12 автодром, 27 автогараж, 257 ату тиры һәм 59 пневматик тир, 122 җиңел һәм 38 йөк автомобиле, 308 мотоцикл, 74 картинг, 33 скутер-глиссер, 111 катер һәм моторлы көймә, 28 шлюпка, 77 акваланг, 35 радиостанция, 3031 кече калибрлы һәм 1200 пневматик винтовка, 518 гимнастика мәйданчыгы, 481 каршылыклар полосасы, сафта йөрергә әзерлек өчен 600 мәйданчык тәшкил итә. 1985 кә ДОСААФ әгъзалары якынча 1 млн. кеше була. ВЦСПС, ВЛКСМ ҮК һәм СССР ДОСААФ ҮКның кучмә Кызыл Байрагы (1970–71, 1975–78, 1982), Вымпелы (1969, 1972, 1974, 1979–81, 1983), Кубогы (1967–68, 1973, 1984–85), СССР Оборона министрлыгының Күчмә Кызыл Байрагы (1977, 1981, 1983–1984) б-н бүләкләнә. РФ Кораллы көчләре өчен белгечләр әзерләү нәтиҗәләре буенча ТР ДОСААФы 2013 тә 5 нче ел рәттән Россиядә 1 нче урынны яулый. Берләшмәнең белем бирү оешмаларында ел саен 20 меңгә якын кеше укый, 2008–16 да 25 меңләп хәрби белгеч әзерләнә.

2016 да ТР ДОСААФы 43 җирле оешманы, 13 авто- һәм техник мәктәпне, 6 спорт-техника клубын, ТР Үзәк аэроклубын үз эченә ала, 250 берәмлек хәрби һәм 300 дән артык гражданнар техникасы бар. Спортның 20 төре: авиамодельләр, автомодельләр, судно модельләре, автомобиль, мотоцикл, самолёт, вертолет, су-мотор, үтә җиңел авиация, парашют, планер, су асты спорты, радиоспорт, җәйге биатлон, комплекслы бергә-бер көрәш, диңгез күп төр ярышы, хезмәт этләре өйрәтү, арбалеттан ату, пейнтбол, ядрә б-н ату спорты үстерелә. ТРның иң яхшы спортчылары (Россия, Европа, дөнья беренчелекләрендә, чемпионатларында, «Икариада» бөтендөнья һава уеннарында катнашучылар, медаль алучылар): М.Абдурахимов, А.А.Бурдов, А.Н.Бурдов, А.Говорова, И.И.Говоров, В.В.Жариков, А.Жихарев, С.С.Клюев, И.М.Кокшагин, К.Г.Крикун, Г.Леонычев, М.Л.Мельников, А.Михайленко, Н.Х.Мухитов, А.Сабодаш, А.Садриев, С.Серебрякин, Л.Хәмитова, А.Харитонов, С.П.Чиков.

Төрле еллардагы җитәкчеләре: Х.З.Габидуллин (1927–30), Х.Ш.Мратхуҗин (1930–32), Х.Г.Хөснетдинов (1934–35), А.С.Будрин (1935), С.С.Касыймов (1935–36), М.Г.Сәйфи (1936–37), В.К.Бельский (1937–38), Н.В.Щербак (1938–41), Б.М.Бикеев (1941–67), Г.Ш.Шакиров (1967–90), Ю.П.Королёв (1990–2003), Р.Р.Зарипов (2003–08), Р.Ф.Моратов (2008 дән).

*Әд.:* Российская оборонная: Энцикл. сб. М., 2002; Зарипов Р.Р. История Татарстанской оборонной организации. К., 2008.

*Н.Д.Бобырев, Р.Р.Зарипов.*

**«ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АРХЕОЛО́ГИК КА́РТАСЫ»,** археол. истәлекләр җыелмасы. «ТР а.к.»н төзү буенча эш Н.Ф.Калинин тәкъдиме б-н 1940 елларда башлана, аннары А.Х.Халиков җитәкчелегендә дәвам иттерелә; 1990 да төгәлләнә. «ТР а.к.»н эшләүдә төрле елларда Һ.В.Йосыпов, Т.А.Хлебникова, Р.Г.Фәхретдинов, П.Н.Старостин, Е.П.Казаков, Р.С.Габәшов, Ф.Ш.Хуҗин һ.б. катнаша. Төрле археол. культураларга нисбәтле 4300 дән артык истәлекне колачлый. «ТР а.к.»нда Татарстан төбәкләрендәге табигый-геогр. шартларга сыйфатлама бирелә, истәлекләрнең өйрәнелү тарихы, кыскача тасвирламасы һәм аларның археол. культураларга нисбәте билгеләнә, истәлекләрнең урнашу карталары тәкъдим ителә. 6 томнан тора: «Татарстан АССРның археологик картасы. Кама алды» (1981); «Татарстан АССРның археологик картасы. Идел алды» (1985); «Татарстан АССРның археологик картасы. Кама аръягы» (1986); «Үзәк Кама аръягы археологик истәлекләре» (1988); «Көнчыгыш Кама аръягы археологик истәлекләре» (1989); «Чирмешән елгасы бассейны археологик истәлекләре» (1990). Һәр томда истәлекләр гомуми нумерация б-н урнаштырылган, аларның күбесе рәсемнәр б-н бирелә. 1994 тә «ТР а.к.»ның төп төзүчеләре ТР Дәүләт бүләгенә лаек була.

*Е.П.Казаков.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ МЕХАНИЗА́ТОРЫ**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1961 ел 5 июнь Указы б-н гамәлгә ашырыла. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан а.х.н механикалаштыру өлкәсендәге казанышлары өчен колхоз, совхоз, фәнни-тикшеренү учреждениеләре һәм башка пр-тие һәм оешмаларның инженер һәм техникларына бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 1344 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ ХЕЗМӘТКӘРЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1985 ел 30 август Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан а.х. өлкәсендәге казанышлары өчен колхозчылар, эшчеләр, хезмәткәрләр, колхоз, совхоз, колхозара пр-тие һәм берләшмә җитәкчеләре, фәнни-тикшеренү учреждениеләре хезмәткәрләре һ.б. белгечләргә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 елның 1 гыйнварына бу исемгә 1247 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н АГРОНОМЫ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1954 ел 23 июнь Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан а.х.н үстерү өлкәсендәге казанышлары өчен колхозлар, совхозлар, фәнни-тикшеренү учреждениеләре һ.б. оешма белгечләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 550 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н АЗЫ́К-ТӨЛЕ́К СӘНӘГАТЕ́ ХЕЗМӘТКӘРЕ́**, мактаулы исем. 1984 елның 25 июнендә ТАССР ЮС Президиумының 1984 ел 25 июнь Указы б-н ТАССРның (1990 нан — ТССР, 1992 дән — ТР) атказанган азык-төлек индустриясе хезмәткәре буларак гамәлгә кертелә, ТРның 2004 ел 24 март Законы б-н хәзерге исемгә алыштырыла. ТР Президенты (1991гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан азык-төлек индустриясе өлкәсендәге казанышлары өчен сәнәгатьнең азык-төлек, ит, сөт һәм шәраб әзерләү тармагы, кулланучылар кооперациясе берләшмәләре, пр-тиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары эшчеләренә, инженер-техник һәм фәнни хезмәткәрләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 102 кеше лаек була. ТРның атказанган азык-төлек индустриясе хезмәткәре исемен 329 кеше йөртә.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н АРТИСТЫ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1940 ел 1 февраль Указы б-н гамәлгә кертелә. Асылда исем 1939 дан бирелә башлый. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан сәнгать өлкәсендәге казанышлары өчен театр, эстрада, цирк артистларына һәм режиссёрларга, ш.у. музыкантларга бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 925 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н АРХИТЕ́КТОРЫ**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1983

ел 7 июль Указы нигезендә гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан шәһәр төзелеше һәм архит-ра өлкәсендәге казанышлары өчен архитекторлар һәм реставраторларга бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 67 кеше лаек була .

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ВЕТЕРИНА́РИЯ ТАБИБЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1954 ел 23 июнь Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан терлекләрнең авыру очракларын кисәтү, терлекчелек һәм кошчылык продуктлылыгын арттыру өлкәсендәге казанышлары өчен колхозлар, совхозлар, вет. участоклары, дәүләт нәсел үрчеткечләре, нәсел з-ды конюшнялары һәм ат з-длары, инкубатор-кошчылык станцияләре, вет. дәваханәләре, бактериол. лаб-яләре, фәнни-тикшеренү учреждениеләре һәм оешмалары вет. табибләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 268 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ГАЗ СӘНӘГАТЕ́ ХЕЗМӘТКӘРЕ́**, мактаулы исем. ТРның 2012 ел 11 июнь Законы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты тарафыннан газүткәргечләр төзү, модернизацияләү һәм куллану, халыкны һәм сәнәгать тармакларын газ б-н тәэмин итү, кадрлар әзерләүдәге казанышлары өчен эшчеләр, мастерлар, инженер-техник, фәнни һәм фәнни-пед. хезмәткәрләргә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 12 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ГЕО́ЛОГЫ**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1986 ел 5 май Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан геология һәм җир асты байлыкларын эзләү өлкәсендәге казанышлары өчен инженер-техник һәм фәнни хезмәткәрләргә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 132 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ҖИҢЕ́Л СӘНӘГА́ТЬ ХЕЗМӘТКӘРЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1984 ел 25 июнь Указы б-н ТАССРның (1990 нан — ТССР, 1992 дән — ТР) атказанган җиңел һәм текстиль (туку) сәнәгате хезмәткәре буларак гамәлгә кертелә, ТРның 2004 ел 24 март Законы нигезендә хәзерге исемгә алыштырыла. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан җиңел сәнәгатьне үстерүдәге казанышлары өчен пр-тиеләр, оешмалар, учреждениеләр, проект-конструкторлык һ.б. оешмалар эшчеләренә, инженер-техник һәм фәнни хезмәткәрләргә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 19 кеше лаек була. ТРның атказанган җиңел һәм туку сәнәгате хезмәткәре исеме 164 кешегә бирелә.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ҖИР ТӨЗҮЧЕСЕ́**, мактаулы исем. 1995 елның 5 июлендә ТР Дәүләт Советының 1995 ел 5 июль карары б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты тарафыннан җир төзү өлкәсендәге казанышлары өчен учреждениеләр, пр-тиеләр, оешмалар һәм уку йортлары эшчеләре, инженер-техник һәм фәнни хезмәткәрләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 34 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ЗООТЕ́ХНИГЫ**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1954 ел 23 июнь Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан терлекчелек һәм кошчылыкны үстерү өлкәсендәге казанышлары өчен колхозлар, совхозлар, дәүләт нәсел үрчеткечләре, нәсел заводы конюшнялары, ат заводлары, инкубатор-кошчылык станцияләре, фәнни-тикшеренү учреждениеләре һәм а.х. оешмалары белгечләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 225 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ИКЪТИСАДЧЫСЫ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1983 ел 21 март Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан икътисад өлкәсендәге казанышлары өчен пр-тиеләр, берләшмәләр, учреждениеләр, оешмалар, министрлыклар, дәүләт ком-тлары һәм ведомстволарның планлаштыру, финанс, банк, стат. органнары, матди-техник тәэминат, икътисад, хисап, ревизия хезмәте белгечләренә, ш.у. икътисад фәне үсешенә һәм кадрлар әзерләүгә керткән өлешләре өчен фәнни һәм фәнни-пед. хезмәткәрләргә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 1822 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н КОТКАРУЧЫСЫ́**, мактаулы исем. ТРның 2004 ел 24 март Законы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты тарафыннан һәлакәт, бәла-каза һәм афәтләрне булдырмау, кисәтү һәм бетерү, коткару техникасын тирәнтен өйрәнү һәм үзләштерү, кадрлар әзерләү өлкәсендәге казанышлары өчен коткару хезмәте хезмәткәрләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 34 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н МАТБУГА́Т ҺӘМ МА́ССАКҮЛӘМ КОММУНИКА́ЦИЯЛӘР ХЕЗМӘТКӘРЕ́**, мактаулы исем. ТРның 2012 ел 11 июнь Законы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты тарафыннан матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге казанышлары өчен матбугат оешмалары һәм органнары, нәшриятлар, полиграфия пр-тиеләре, матбугат хезмәткәрләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 43 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н МАШИНА́ ТӨЗҮЧЕСЕ́**, мактаулы исем. 1980 елның 12 сентябрендә ТАССР ЮС Президиумының 1980 ел 12 сентябрь Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан машина төзү өлкәсендәге казанышлары өчен пр-тиеләр, берләшмәләр, фәнни-тикшеренү, технол., проект-конструкторлык һ.б. оешмалар эшчеләре, осталары, инженер-техник һәм фәнни хезмәткәрләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 елның 1 гыйнварына бу исемгә 1009 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ́ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ́ ХЕЗМӘТКӘРЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮСның 1982 ел 30 март Указы б-н ТАССРның (1990 нан — ТССР, 1992 дән — ТР) атказ. элемтәчесе буларак гамәлгә кертелә, ТРның 2004 ел 24 март Законы б-н ТРның атказанган элемтә хезмәткәре дип үзгәртелә, ТРның 2011 ел 10 октябрь Законы б-н хәзерге исемгә алыштырыла. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан элемтә өлкәсендәге казанышлары өчен элемтә пр-тиеләре һәм оешмалары, уку йортлары хезмәткәрләре, ш.у. министрлыклар, ведомстволар белгечләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 46 кеше лаек була. ТРның атказанган элемтәчесе исеме 158 кешегә бирелә.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н МӘДӘНИЯ́Т ХЕЗМӘТКӘРЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1965 ел 3 август Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан мәдәният өлкәсендәге казанышлары өчен мәдәният йортлары һәм сарайлары, клублар, музейлар, парклар, китапханәләр, методик кабинетлар, кинотеатрлар, кино кую җайланмалары, нәшриятлар, полиграфияләр, китап сәүдәсе, радиотапшырулар, телевидение, уку йортлары һ.б. оешмалар хезмәткәрләренә, ш.у. үзешчән сәнгатьтә катнашучыларга бирелә. Әлеге исем б-н гуманитар өлкәгә караган кайбер башка категория вәкилләренең — язучылар, мәгариф хезмәткәрләре һ.б.ның казанышлары да билгеләп үтелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 2768 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н МЕЛИОРА́ТОРЫ**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1976 ел 4 июнь Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты тарафыннан (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) мелиорация өлкәсендәге казанышлары өчен белгечләргә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк

билгесе б-н биргә тапшырыла. 2015 елның 1 гыйнварына бу исемгә 164 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н НЕ́ФТЬЧЕСЕ**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1971 ел 11 май Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан нефть һәм газ сәнәгатен үстерү өлкәсендәге казанышлары өчен пр-тиеләр, оешмалар һәм уку йортлары эшчеләренә, инженер-техник һәм фәнни хезмәткәрләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 981 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н РАЦИОНАЛИЗА́ТОРЫ**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1985 ел 7 июнь Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан рационализаторлык тәкъдимнәре җитештерүне камилләштерүдә кулланылган авторларга бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 74 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н СӘЛАМӘТЛЕ́К САКЛА́У ХЕЗМӘТКӘРЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1985 ел 24 июнь Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан сәламәтлек саклау һәм фармакол. өлкәсендә, кадрлар әзерләүдә һәм әйләнә-тирә мохитне саклауда ирешкән казанышлары өчен урта мед., фарм. персоналы һ.б. хезмәткәрләргә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 318 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н СӘНГА́ТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1940 ел 1 февраль Указы б-н гамәлгә кертелә. Нигездә, 1939 дан бирелә башлый. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан сәнгать өлкәсендәге казанышлары өчен режиссёрлар, композиторлар, дирижёрлар, рәссамнар, скульпторлар, архитекторлар һ.б.га бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 625 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н СӘҮДӘ́ ХЕЗМӘТКӘРЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1979 ел 29 октябрь Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан сәүдә өлкәсендәге казанышлары өчен ваклап һәм күмәртәләп сату, җәмәгать туклануы, уку йортлары, хәзерләүләр, тәэминат һ.б. оешма һәм пр-тиеләр хезмәткәрләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. Бу исемгә 618 кеше лаек була. ТРның 2004 ел 24 март Законы нигезендә гамәлдән чыгарыла.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ТАБИБЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1940 ел 1 февраль Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары өчен хастаханәләр, клиникалар, поликлиникалар, амбулаторияләр, бала тудыру йортлары һ.б. дәвалау-профилактика һәм сан. учреждениеләре табибләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 1962 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ТЕРЛЕКЧЕСЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1973 ел 31 гыйнвар Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан терлекчелек өлкәсендәге казанышлары өчен колхозлар, совхозлар һ.б. а.х. пр-тиеләре һәм оешмалары хезмәткәрләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 778 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ТОРА́К-КОММУНА́ЛЬ ХУҖАЛЫ́К ХЕЗМӘТКӘРЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1978 ел 26 октябрь Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге казанышлары өчен пр-тиеләр, оешмалар, фәнни-тикшеренү, проект-конструкторлык учреждениеләре һәм оешмалары хезмәткәрләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 512 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ТӨЗҮЧЕСЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1960 ел 18 июль Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан төзелеш өлкәсендәге казанышлары өчен төзелеш, монтаж, проект оешмалары һәм төзелеш материаллары сәнәгате пр-тиеләре эшчеләре, инженерлары, техниклары һәм хезмәткәрләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 2797 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ТРА́НСПОРТ ХЕЗМӘТКӘРЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1980 ел 16 май Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР,ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан транспорт өлкәсендәге казанышлары өчен автомобиль, су, һава, тимер юл транспорты, ш.у. башка тармакларга караган транспорт оешмалары һ.б. пр-тие хезмәткәрләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 1161 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н УЙЛА́П ТАБУЧЫСЫ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1985 ел 7 июнь Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан техник прогрессны үстерүгә керткән өлеше өчен уйлап табу авторларына бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 99 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н УКЫТУЧЫСЫ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1940 ел 1 февраль Указы б-н ТАССРның (1990 нан — ТССР, 1992 дән — ТР) атказанган мәктәп укытучысы буларак гамәлгә кертелә, ТРның 2011 ел 10 октябрь Законы б-н исеме үзгәртелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан мәктәп укытучылары, директорлар, укыту бүлеге мөдирләре һәм мәктәпләр буенча инспекторлар, пед. уч-щеләре укытучылары, пед. кабинетлары, халык мәгарифенең район һәм шәһәр бүлекләре мөдирләренә балалар тәрбияләү һәм укыту эшендәге уңышлары өчен бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 2331 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н УРМАНЧЫСЫ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1967 ел 28 декабрь Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан урман хуҗалыгын үстерүдәге казанышлары өчен урман хуҗалыгы, урман хуҗалыгы сәнәгате, урман һәм җиләк-җимеш агачлары питомниклары, колхозлар, совхозлар, фәнни-тикшеренү, урман төзелеше, проектлау-эзләнү һ.б. оешмалар һәм учреждениеләр белгечләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 159 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ФӘН ҺӘМ ТЕ́ХНИКА ЭШЛЕКЛЕСЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1940 ел 1 февраль Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан фән һәм техника өлкәсендәге казанышлары, ачышлары һәм уйлап табулары, ш.у. фәнни-гамәли һәм фәнни белемнәрне популярлаштырудагы эшчәнлекләре өчен галимнәргә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. Бу исемгә 295 кеше лаек була. ТРның 2004 ел 24 март Законы нигезендә гамәлдән чыгарыла.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ФӘН ЭШЛЕКЛЕСЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1940 ел 1 февраль Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан фән өлкәсендәге казанышлары, ачышлары һәм уйлап табулары, ш.у. фәнни-гамәли һәм фәнни белемнәрне популярлаштырудагы эшчәнлекләре өчен галимнәргә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 818 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ФИ́ЗИК КУЛЬТУ́РА ХЕЗМӘТКӘРЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1983 ел 9 август Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан физкультура хәрәкәтен оештыручыларга, галимнәр, тренерлар һ.б. хезмәткәрләргә физик культура һәм спортны үстерүдәге казанышлары өчен бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына 491 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ХАЛЫККА́ КӨ́НКҮРЕШ ХЕЗМӘТЕ́ КҮРСӘТҮ́ ХЕЗМӘТКӘРЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1978 ел 15 сентябрь Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү өлкәсендәге казанышлары өчен пр-тие, берләшмә, идарә, фәнни-тикшеренү, проект-конструкторлык һ.б. учреждение һәм оешма хезмәткәрләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. ТРның 2004 ел 24 март Законы нигезендә гамәлдән чыгарыла. Бу исемгә 234 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ХАЛЫКНЫ́ СОЦИА́ЛЬ ЯКЛА́У ХЕЗМӘТКӘРЕ́**, мактаулы исем. ТР Дәүләт Советының 2001 ел 24 май карары б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты тарафыннан халыкка социаль ярдәм оештыру, яклау, иминиятләштерү һәм эш б-н тәэмин итүдә, мохтаҗларга хәйрия ярдәме күрсәтүдә, ш.у. әлеге өлкәдә фәнни тикшеренүләр үткәрүдәге казанышлары өчен социаль яклау системасы органнары, учреждениеләре һәм пр-тиеләре хезмәткәрләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 148 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ХИ́МИГЫ**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1983 ел 20 май Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан химия өлкәсендә, химия һәм нефть химиясендә җитештерү объектларын төзү һәм үстерүдәге казанышлары өчен пр-тиеләр, берләшмәләр, фәнни-тикшеренү, технол., проект-конструкторлык һ.б. оешмалар эшчеләренә, осталарга, инженер-техник, фәнни һәм фәнни-пед. хезмәткәрләргә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 565 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ЭКО́ЛОГЫ**, мактаулы исем. ТРның 2004 ел 24 март Законы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты тарафыннан экология өлкәсендә ирешкән казанышлары өчен пр-тиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр эшчеләренә һәм хезмәткәрләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 29 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ЭНЕРГЕ́ТИГЫ**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1979 ел 6 декабрь Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан энергетика өлкәсендәге казанышлары өчен электростанцияләр, электр һәм җылылык челтәрләре, ремонт һәм төзәтү пр-тиеләре, фәнни-тикшеренү, проект һ.б. оешмалар һәм уку йортлары эшчеләренә, инженер-техник, фәнни хезмәткәрләргә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 677 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ЭЧКЕ́ ЭШЛӘ́Р О́РГАННАРЫ ХЕЗМӘТКӘРЕ́**, мактаулы исем. ТР Дәүләт Советының 2000 ел 19 май карары б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты тарафыннан тәртип саклау, җинаятьчелек б-н көрәш, җәмгыять иминлеген, хокук фәннәре үсешен тәэмин итү, белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен эчке эшләр хезмәткәрләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 157 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ЮГАРЫ́ МӘКТӘ́П ХЕЗМӘТКӘРЕ́**, мактаулы исем. ТРның 2004 ел 24 март Законы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты тарафыннан укыту һәм фәнни эштәге, кадрлар әзерләүдәге казанышлары өчен югары белем, югары уку йортыннан соң һөнәри өстәмә белем бирү системасы һәм дәүләт югары белем бирү идарәсе органнары системасы хезмәткәрләренә, укытучыларга бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 55 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ЮРИСТЫ́** (хокук белгече), мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1984 ел 27 февраль Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан Законнарның үтәлешен ныгыту, юридик фәннәрне үстерүдәге казанышлары, ш.у. гамәли һәм фәнни-пед. эшчәнлекләре өчен хокук белгечләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 елның 1 гыйнварына бу исемгә 683 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГА́Н ЯШЬЛӘ́Р СӘЯСӘТЕ́ ӨЛКӘСЕ́ ХЕЗМӘТКӘРЕ́**, мактаулы исем. ТРның 2015 ел 25 апрель Законы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты тарафыннан яшьләр сәясәте өлкәсендә казанышларга ирешкән хезмәткәрләргә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ А́УДИО-ВИЗУА́ЛЬ ДОКУМЕНТЛӘ́Р ДӘҮЛӘ́Т ҮЗӘ́К АРХИВЫ́**. 2000 елда ТР МК карары нигезендә оештырыла, МК каршындагы *Баш архив идарәсенең* аерым структура бүлекчәсе. Архив аудио-визуаль документларны саклый, үзәкләштереп терки; аларны элекке хәленә кайтара, саклый, иминиятләштерү өчен күчермәсен ала, аеруча кыйммәтле документларны ачыклый һәм исәбен алып бара; дәүләтнеке булмаган учреждениеләрдән, иҗтимагый оешмалардан һәм гражданнардан аудио-визуаль документларны, чит ил һәм Россия архивларыннан үз профилендәге документларның күчермәләрен һәм төп нөсхәләрен даими саклау өчен кабул итә, сайлап ала һәм экспертиза ясый; мәгълүматлар базасы булдыра; актуаль тематика буенча документлар нәшер итә; архив документларының составы һәм эчтәлеге турында юл күрсәткечләр һ.б. белешмәлекләр әзерләү б-н шөгыльләнә. 2012 ел башына ТР А.-в.д.д.ү.а.нда 25757 саклау берәмлеге, ш.и. 23931 фотодокумент, 67 видеодокумент, 255 фонодокумент, 1192 кинодокумент, 312 машина укый торган документ исәпләнә. Архивта ТР терр-ясендә эшләгән һәм эшләүче учреждениеләр, оешмалар һәм пр-тиеләрнең эшчәнлеге процессында барлыкка килгән иҗтимагый-сәяси, икътисади, фәнни, соц.-мәдәни яки тарихи әһәмияткә ия ТР Архив фонды документаль киноматериаллары, документаль һәм нәфис фотодокументлар, аудио-, видеоязмалар; Россиядәге һәм чит илләрдәге башка архивлардагы Татарстан тарихына кагылышлы аудио-визуаль документларның күчермәләре; аеруча кыйммәтле аудио-визуаль документ күчермәләренең иминият фонды; исәп-хисап документлары, архив белешмәлекләре, мәгълүматлар базасы; матбугат басмалары һ.б. материаллар саклана. Фотодокументлар аклы-каралы, төсле негативларда, позитивларда, слайдларда, санлы фотодокументлар электрон тараткычларда саклана. Фотодокументлар архивка «Молодёжь Татарстана», «Республика Татарстан», «Ватаным Татарстан», «Казанские ведомости», «Сабантуй», «Время и деньги», «Шәһри Казан», «Мәдәни җомга», «Милиция. Законность. Правопорядок» г-талары редакцияләреннән; «Казань», «Сөембикә», «Сәхнә» ж-ллары редакцияләреннән, «Шәһәрләр һәм авыллар буйлап» («По городам и весям») нәшриятыннан, ТР Татар фольклорын җыю, саклау, өйрәнү һәм пропагандалау дәүләт үзәгеннән; «Казан посады» префектурасыннан; К.Тинчурин исем. Татар драма һәм комедия театрыннан алына. Фондларда аерым шәхесләрнең (язучы Т.Г.Миңнуллин, музыка белгече Ф.Т.Арсланова, «Ватаным Татарстан» г-тасы фотохәбәрчесе М.Ф.Шакирҗанов, арх. Н.Х.Халитов һ.б.) фотодокументлар коллекциясе тәкъдим ителә. Кинодокументлар «Киң Иделдә» («На Волге широкой») киножурналы, Казан кинохроника студиясе (1975–77), Н.И.Лобачевский исем. Фәнни китапханә кинодокументларыннан (1954, 1967, 1975–77) туплана, респ-ка төзелү, аның сәяси һәм икътисади үсешенең төп этаплары турында кинохроника, сугыш еллары хроникасы кадрлары һ.б. бар. Архивта саклanучы видеодокументларның төп өлешен «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе тапшыра; ш.у. «Казан посады» префектурасы, Казан шәһәре администрациясенең Мәдәният идарәсе, ТР Татар фольклорын җыю, саклау, өйрәнү һәм пропагандалау дәүләт үзәге, ТР МК каршындагы Баш

архив идарәсе һ.б. материаллары да шактый зур урын тота. Архив фонотекасында 1994–96 еллардагы ТР Дәүләт Советы утырышлары, муз. фольклор (халык җырлары, инструменталь фольклор), популяр музыка (хәзерге татар, рус, башкорт авторларының җырлары, тынлы оркестр, халык музыка уен кораллары өчен музыка, спектакльләргә музыка), симф., опера, хор, камера музыкасы, театр спектакльләре язмалары, иҗади укулар аудиоязмалары һ.б. саклана. Архивта 2001–07 дә ТРның Аудио-визуаль документлар дәүләт үзәк архивына кабул ителгән кино-, видео-, фоно-, фотодокументларның тематик базасы, фонодокументлар каталог-белешмәлеге бар. Директоры — С.Н.Горохов (2000 нән).

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ БАЛАЛА́Р ҺӘМ ЯШЬЛӘ́Р ЭШЛӘРЕ́ ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**. ТР ЮСның 1993 ел 2 март карары нигезендә оештырыла. Эшчәнлеген 1994 нең 22 августында башлый. Яшьләр сәясәте өлкәсендә тармакара килештерү һәм көйләү эшләрен гамәлгә ашыра. Дәүләт ком-ты составына ТР шәһәрләре һәм районнарының хакимият башлыклары каршындагы яшьләр эшләре бүлекләре, Балигъ булмаганнарны социаль-хокукый яклау үзәге, Респ-ка яшьләр хезмәт биржасы, балалар һәм яшьләр оешмалары керә. ТР Президентына, ТР МКна һәм РФнең Яшьләр эшләре буенча дәүләт ком-тына буйсына. ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май карары нигезендә гамәлдән чыгарыла, вазифалары *Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына* тапшырыла. Рәисе — М.М.Бариев (1994–2001).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ВӘКИЛЛЕКЛӘРЕ́**, ТР дәүләт органнары. ТР дәүләт хакимияте органнарының РФ һәм аның субъектларындагы дәүләт хакимияте федераль органнары б-н, ш.у. чит илләрдәге дәүләт учреждениеләре һәм оешмалары (фирмалары) б-н үзара багланышларын тәэмин итү өчен оештырыла. ТРның 2003 ел 13 ноябрь Законы буенча ТР җитәкчелеге тулы вәкаләтле, даими һәм сәүдә-икътисад вәкиллекләре, халыкара оешмалар каршында даими вәкиллекләр төзи ала. ТРның тулы вәкаләтле вәкиллекләре, кагыйдә буларак, чит илләр терр-ясендә, даими вәкиллекләр һәм сәүдә-икътисад вәкиллекләре РФ субъектларында яки чит илләрдәге РФ дипломатик һәм сәүдә вәкиллекләрендә (кайвакыт ике як килешүе буенча мөстәкыйль оешма буларак) сәүдә-икътисади, фәнни-техник, гуманитар, мәдәни һ.б. өлкәләрдә Татарстан мәнфәгатьләрен тәэмин итү максатыннан барлыкка килә. ТРның халыкара оешмалар каршындагы даими вәкиллекләре респ-ка мәнфәгатьләрен үткәрә. Т.Р.в. ТР Президенты карары нигезендә яки аның кушуы буенча ТР МКның федераль хакимият органнары б-н килешүе нигезендә, РФ субъектлары б-н килешүләр нигезендә оештырыла һәм ТР дәүләт хакимиятенең башкарма органнары системасына керә. Т.Р.в. Президентка һәм ТР МКна буйсыналар. Т.Р.в. эшчәнлеген ТР Президенты Тышкы мөнәсәбәтләр департаменты координацияли. Т.Р.в. б-н 3 елга ТР Президенты билгеләгән вәкил җитәкчелек итә (ләкин эшләү вакыты рәттән 2 сроктан артмый).

ТССРның дәүләт суверенлыгы турындагы Декларация игълан ителгәннән соң (1990), Татарстан җитәкчелеге, вәкиллекләр ачып, Россия төбәкләре һәм чит илләр б-н сәүдә-икътисад, фәнни-техник, гуманитар, мәдәни һ.б. мөнәсәбәтләр урнаштыру буенча актив эш алып бара башлый. 1994 тә Мәскәүдә ТРның РФдә беренче тулы вәкаләтле вәкиллеге ачыла. Аннары шундый вәкиллекләр РФнең башка шәһәрләрендә һәм өлкәләрендә дә барлыкка килә: Свердловск өлкәсендә (1996, Екатеринбург ш.), С.-Петербургта һәм Ленинград өлкәсендә (1996, С.-Петербург), Кырым Республикасында (2014, Севастополь ш.) — ТРның даими вәкиллекләре; Түбән Новгород өлкәсендә (2001, Түбән Новгород ш.), Ханты-Манси автономияле округында (2001, Сургут ш.), Саратов өлкәсендә (2002, Саратов ш.) — ТРның сәүдә-икътисад вәкиллекләре һ.б. Бер үк вакытта Т.Р.в. чит илләрдә дә ачыла: тулы вәкаләтле вәкиллекләр — Франциядә (1994, Париж), Австралия Берлегендә (1995–2000, Аделаида ш.), Казакъстанда (1997, Астана, Алма-Ата ш.), Төркиядә (1997, Истанбул); даими вәкиллекләр — Әзәрбайҗанда (1992, Баку), Үзбәкстанда (1992, Ташкент); сәүдә вәкиллекләре — АКШта (1994, Вашингтон), Украинада (1994, Киев), Литвада (1993–98, Каунас ш.), Австриядә (1994–2006, Вена), Кипр Респ-касында (1997, Никосия); сәүдә-икътисад вәкиллекләре — Чех һәм Словакия Респ-каларында (1996, Прага), Финляндиядә (2000, Хельсинки), Кубада (1999, Гавана), Вьетнамда (2000, Ханой), Белоруссия Респ-касында (2002, Минск), Швейцариядә (2002, Женева), Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә (2013, Дубай), Кытай Халык Респ-касында (2014, Пекин) һ.б. 2015 нең 1 гыйнварына 22 Т.Р.в. эшли (14 е чит илдә, 8 е РФдә), аларның 13 е ТР дәүләт бюджетыннан финанслана. Татарстан Респ-касында эшләүчеләр саны — 102 кеше, ш.и. 70 тән артык кеше — РФдәге Т.Р.в.ндә.

Т.Р.в. Татарстан компанияләренә һәм сәүдә фирмаларына товарларны чит илләргә чыгару һәм илгә кертү буенча контрактлар һәм килешүләр төзүдә, уртак пр-тиеләр булдыруда, ТРга чит ил инвестицияләрен һәм кредитларын җәлеп итүдә, Россия төбәкләренә һәм чит илләргә ТР делегациясе визитларын оештыруда, ТРдан читтә татарлар күпләп яшәгән урыннарда массакүләм-мәдәни чаралар (концертлар, фестивальләр, иҗади кичәләр, Сабан туйлары һ.б.) оештыруда актив булышлык итәләр. ТРдан читтәге ватандашларына ярдәм күрсәтәләр, татар мәдәниятен һәм телен үстерү, татар диаспорасының этномәдәни үзенчәлекләрен саклау буенча эш алып баралар. Ш.у.к. *Татарстан Республикасының РСФСРдагы вәкаләтле вәкиллеге.*

*И.М.Галиев.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ГАБДУЛЛА́ ТУКА́Й ИСЕМЕНДӘГЕ́ ДӘҮЛӘ́Т БҮЛӘГЕ́**. КПССның Татарстан өлкә ком-ты һәм ТАССР МСның 1958 ел 8 апрель һәм 1965 ел 11 октябрь карарлары б-н гамәлгә кертелә (1961–65 тә бирелми). Аерым затлар һәм авторлар коллективына иҗади казанышлары, югары һөнәри осталык б-н аерылып торган, яңалык алып килгән, стиль үзенчәлегенә һәм оригинальлеккә ия әдәбият һәм сәнгать әсәрләре, ш.у. сәнгать һәм әдәбият белеме өлкәсендәге фәнни эзләнүләре өчен бирелә. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләкләре комиссиясе тәкъдиме б-н елга бер тапкыр ТР Президенты (1991 гә кадәр ТАССР ЮС Президиумы) тарафыннан, бүләкләнүчеләргә лауреат исеме бирелеп, күкрәк билгесе һәм диплом б-н бергә тапшырыла. 2016 елның 1 гыйнварына бу бүләккә 193 кеше, ТРның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле һәм ТРның Дәүләт кыллы квартеты лаек була.

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ГЕОЛО́ГИЯ ҺӘМ ҖИР АСТЫ́ БАЙЛЫКЛАРЫ́Н ФАЙДАЛАНУ́ ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**. ТР Дәүләт Советының 1996 ел 25 апрель карары нигезендә оештырыла. Җир асты байлыкларының геологиясен өйрәнүне, нигезле файдалануны һәм саклауны, минерал чимал базасын кабат тергезүне оештыру эшләрен башкара. Үз эченә секретариатны; файдалы казылмалар запасы; нефть, газ һәм битум чыганакларында геол.-разведкалау һәм фәнни-методик эшләр; катламнарның нефть бирүчәнлеген күтәрү һәм табигый битумны үзләштерү; төбәк эшчәнлеге һәм геол. контроль; каты файдалы казылмалар геологиясе һәм гидрогеологиясе бүлекләрен ала. ТР Президентына һәм ТР МКна буйсына. ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май карары нигезендә гамәлдән чыгарыла, вазифалары Татарстан Респ-касының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына тапшырыла. Рәисе — Ф.М.Хәйретдинов (1997–2001).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘ́Т ҖЫР ҺӘМ БИЮ́ АНСА́МБЛЕ**. 1937 елда хор капелласы буларак оеша. 1938 дән — Җыр, бию һәм музыка ансамбле, 1957 дән — ТАССРның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, 1992 дән хәзерге исемендә. 1991 гә кадәр Татар филармониясе составына керә. Коллектив эшчәнлегенең төп максаты — милли вокаль һәм хореография сәнгате традицияләрен саклау һәм үстерү. Ансамбль иҗатының нигезендә — татар халкының фольклор мирасын сәхнә югарылыгына җиткерү. Беренче сәнгать җитәкчесе — З.Әхмәтова. Ансамбльнең иҗади йөзен формалаштыруга комп. һәм фольклорчы А.Ключарёв, балетмейстерлар Ф.Гаскәров, Г.Таһиров зур өлеш кертә. Оешкан вакытта составында 16 хор артисты, алар арасында А.Бормусов (сәнгать җитәкчесе), И.Грекулов (хормейстер), А.Миндубаев, В.Шакиров була. 1938 дә 6 кешедән торган бию төркеме оеша (балетмейстер Ю.Муко).

Ансамбльнең беренче концерты 1938 нең 30 апрелендә була, беренче гастрольләре 1939 ның җәендә Кавказ арты респ-каларында уза. Сугышка кадәрге репертуарын татар халык җырлары эшкәртмәләре, татар композиторлары җырлары, рус халык җырлары һәм совет композиторларының татар телендәге



Сулдан уңга: ансамбльнең сәнгать җитәкчесе З.Әхмәтова, дирижёр А.Пирогов, филармония директоры Б.Абдуллин, композитор А.Ключарёв. 1941.

җырлары; төрле халыкларның биюләре тәшкил итә. Коллектив б-н композиторлар В.Виноградов, М.Мозаффаров, З.Хәбибуллин һ.б. хезмәттәшлек итә. Бөек Ватан сугышы елларында ансамбль труппасы, концерт бригадаларына бүленеп, фронт һәм фронт алды зонасы сугышчыларына, ш.у. тыл хезмәтчәннәренә йөзләгән тамаша күрсәтә. 1940 ның 2 нче яртысы — 1950 дә коллективның гастроль чыгышлар географиясе киңәя: Урта Азия, Казакъстан, Урал һәм Себер шәһәрләре, Украина, Молдавия һ.б. Вокаль репертуар А.Ключарёв («Әллүки», «Кара урман»), Җ.Фәйзи («Рәйхан»), М.Латыйпов («Казан сөлгесе», «Ай, былбылым»), М.Мозаффаров («Сибелә чәчәк»; Г.Тукай шигырьләренә «Зиләйлүк» һәм «Тәфтиләү») эшкәртүләрендәге татар халык җырлары б-н тулылана. Авторлы әсәрләр арасында С.Габәшинең «Кәккүк» (Ә.Ерикәй шигыре), С.Сәйдәшевнең «Бибисара» һәм «Дуслык җыры» (Ә.Ерикәй шигырьләре), А.Ключарёвның «Идел дулкыннары» (М.Хөсәен шигыре), З.Хәбибуллинның «Бормалы су» (Н.Исәнбәт шигыре), М.Мозаффаровның «Казан турында җыр» (Х.Вахит шигыре) һ.б. җырлар бар. Хореография репертуары фольклор нигезендә төзелә. «Су буенда», «Басмада бию», «Җизнәкәй» (балетмейстер Ф.Гаскәров), «Мәдрәсәдә булган хәл», «Батраклар», «Көтүче һәм сыер савучы» (балетмейстер Г.Таһиров), «Гармуннар белән бию», «Дуслык» сюитасы (балетмейстер А.Янкин), «Әпипә», «Егетләр» (балетмейстер Ә.Кәлимуллин) һ.б. сюжетлы бию композицияләре эшләнә.

1960–90 елларда ансамбль Татарстан композиторлары б-н актив хезмәттәшлеген дәвам итә. Татар халык көйләренең яңа эшкәртмәләре һәм автор җырлары, бию постановкалары барлыкка килә; вокаль-хореография композицияләре һәм тематик концерт программалары оештырыла: «Аулак өй», «Сабантуй» (комп. А.Ключарёв, балетмейстер Ф.Гаскәров), «Гөлләрем», «Казан кунаклары» (комп. З.Хәбибуллин, балетмейстер Г.Таһиров), «Сарман хороводы» (комп. Ә.Абдуллин, балетмейстер Г.Таһиров). 1980–90 да ансамбль репертуары яңа программалар б-н тулылана. Л.Кустабаева җитәкчелегендә сәхнәләштерелгән «Сабантуй», «Ватаным минем», «Безнең мирас», «Раушан көзге», «Урал моңнары», «Сәйдәшем», «Каз өмәсе», «Төрки дөнья», «Корбан бәйрәме», «Шәрекъ клубы», «Йолдызлар сүнми», «Әрни әле, әрни ул яра», «Чишмә», «Рамазан» һ.б. вокаль-хореография күренешләре, А.Хәмитов җитәкчелегендә «Казан турында риваять» («Сказание о Казани»), «Истанбул турында хыяллар» («Грёзы Станбула»), «Җиде энҗе», «Кызыл ромашка» программалары гамәлгә ашырыла.



Татар «Әпипә» биюе. Сәхнәгә куючы – ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе Ә.Кәлимуллин. Солистлар – Е.Никонова һәм ТАССРның халык артисты Ф.Гыймадиев.



Театральләштерелгән вокаль-хореографик «Аулак өй» куелышы. Сәхнәгә куючы – РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе Ф.Гаскәров. А.Ключарёв музыкасы. Н.Исәнбәт либреттосы.

Төрле елларда ансамбльдә — хормейстерлар А.Бормусов, И.Грекулов, А.Мусина, С.Саттарова, Җ.Котдусов; балетмейстерлар Ф.Гаскәров, Г.Таһиров, Ә.Кәлимуллин, А.Янкин, Ә.Нарыйков; җырчылар Р.Тимерханова, Г.Гафиятуллина, Ә.Авзалова, С.Йосыпов, Т.Якупов, З.Әхтәмова, Н.Василова, Ш.Әхмәтҗанов, М.Садыйков, А.Туишева; биючеләр Ф.Абдуллина, А.Бирючевский, М.Гатиятуллин, Ф.Гыймадиев, Ә.Кретова, Р.Габдрахманов, Р.Мостафина, Ф.Фәйзуллин, Т.Латыйфуллин, В.Кузнецов, А.Хәмитов, Л.Хәмитова һ.б. 2015 тә труппа составында — 28 хор төркеме артисты, шулар арасында 19 солист; 31 биючеләр төркеме артисты; 15 оркестр музыканты. Сәнгать җитәкчесе — А.Хәмитов, баш балетмейстер — Р.Гарипова, баш хормейстер — Н.Гәрәев, оркестр җитәкчесе — Р.Мостафин.

Ансамбль Төньяк Корея (1958), Кытай (1960), Монголия (1966), Тунис (1977), Италия һәм Мальта (1978), Нигерия, Сенегал, Бенин (1979), ГДР (1980), Чехословакия (1981), Япония (1987), Йәмән (1988), ГФР һәм Финляндия (1989), Төркия (1991, 1993), Франциягә (1996) гастрольләр б-н бара. 1939 да (2 нче урын), 1945 тә (1 нче урын), 1986 да (1 нче урын) — бөтенроссия, 1977 дә (Карфаген, Тунис, 1 нче урын) — халыкара һ.б. смотр, конкурс, фестивальләр лауреаты. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә ия була (1960). Халыклар дуслыгы ордены б-н бүләкләнә (1988). Төрле елларда ансамбльнең сәнгать җитәкчеләре: З.Әхмәтова (1938–59), Җ.Айдаров (1959–65), Ә.Абдуллин (1967–68), А.Ключарёв (1939, 1968–70), Г.Скалозубов (1974–78), Л.Кустабаева (1978–2002), А.Хәмитов (2005 тән).



Вокаль-хореографик «Каз өмәсе» куелышы. Сценарий авторы һәм сәхнәгә куючы – РФнең халык артисты Л.Кустабаева. ТРның халык артисты Т.Латыйфуллин хореографиясе. ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе Ә.Абдуллин, ТАССРның халык артисты Р.Мостафин музыкасы.

*Әд.:* З ә й н а ш е в а Г. Чын безнеңчә матур, милли... // Казан утлары. 1993. № 11; Ансамбль песни и пляски Советской Татарии // Советская музыка. 1950. № 12; Щ е р б а к о в а Р. Обогащая традиции // Коммунист Татарии. 1990. № 2; А л м а з о в а А. В песне и танце — душа народа // Татарстан. 1990. № 1.

*В.Н.Горшков.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘ́Т КЫЛЛЫ́ КВАРТЕТЫ́**. 1996 елда Казан консерваториясе педагогларының 1980 дә төзелгән кыллы квартеты җирлегендә оеша. Составында — Ш.*Монасыйпов* (1 нче скрипка), М.*Зарипов* (2 нче скрипка), К.*Монасыйпов* (альт; 2011 дән — Ә.Корбангалиев), А.*Әсәдуллин* (виолончель). Репертуарын дөнья классикасы әсәрләре, заманча музыка, Татарстан композиторларының муз. әсәрләре (Ф.Әхмәтов, Р.Еникиев, Р.Кәлимуллин, Р.Ахиярова, М.Мозаффаров һ.б.ның квартет музыкасы), татар дини көйләре (китап көйләре, мөнәҗәтләр һ.б.) һәм халык көйләре



ТРның Дәүләт кыллы квартеты: Шамил Монасыйпов — 1 нче скрипка, Марат Зарипов — 2 нче скрипка, Камил Монасыйпов — альт, Альберт Әсәдуллин — виолончель.

эшкәртмәләре тәшкил итә. Башкаруы истә калырлык эмоциональ тәэсирлелеге, югары зәвыгы, ансамбль б-н уйнау техникасы б-н виртуозларча эш итә белүе ягыннан аерылып тора. Квартет даими рәвештә халыкара заманча һәм классик музыка фестивальләрендә («Мәскәү көзе» («Московская осень»), «Петербург язы» («Петербургская весна»), «Төньяк Пальмирада Раштуа кичләре» («Рождественские вечера в Северной Пальмире»), «Урал асылташлары» («Уральские самоцветы»), «Европа-Азия») катнаша. Япония, Германия, Италия, Финляндия, Төркия, Франция, Словакия, Һиндстан, Австралия, Малайзия, АКШ, Англия, Чехиягә гастрольләр б-н бара. Ансамбль язмалары б-н компакт-дисклар Япония (1994, 1996), АКШ (1997), Россиядә (1998, 1999, 2000) чыга. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге (1987), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (2002) лауреаты.

*Ш.Х.Монасыйпов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘ́Т МӨЛКӘТӘ́ БЕЛӘ́Н ИДАРӘ́ ИТҮ́ ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**. ТССР ЮСның 1991 ел 7 февраль карары нигезендә оештырыла; ТР Дәүләт Советының 1995 ел 22 июнь карары б-н ТРның Сәнәгать сәясәте һәм дәүләт мөлкәте б-н идарә итү дәүләт ком-ты итеп үзгәртелә; ТР Дәүләт Советының 1996 ел 27 ноябрь карары б-н ТРның Дәүләт мөлкәте б-н идарә итү дәүләт ком-ты буларак кабат торгызыла. Сәнәгать өлкәсендә сәясәт үткәрү, дәүләт мөлкәте б-н идарә итү, икътисадны хосусыйлаштыру һәм монополиядән чыгару чараларын гамәлгә ашыра. Сәнәгать департаментын; дәүләт милкен исәпкә алу, дәүләт милкен урнаштыру; АҖ, холдинг компанияләре һәм траст мөнәсәбәтләре; инвестицияләр һәм фонд базары; аренда, залог мөнәсәбәтләре һәм яңа икътисади структуралар; хезмәтне оештыру һәм мәгълүмат идарәләрен үз эченә ала. Дәүләт ком-ты системасына Респ-ка банкротлык эшләре агентлыгы; ТР хосусыйлаштыру фонды; Респ-ка бюджеттан тыш гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре фонды; Үзәк депозитарий; Сәнәгать, бизнес һәм хосусыйлаштыру дәүләт ин-ты; Респ-ка җитәкче кадрларның квалификациясен күтәрү һәм кабаттан әзерләү укыту–тикшеренү үзәге; дәүләт пр-тиеләре һәм учреждениеләре; ш.у. устав капиталында дәүләт кертеме булган хуҗалык оешмалары (ширкәтләре) керә. ТР Президентына, ТР МКна һәм РФнең Дәүләт мөлкәте министрлыгына буйсына. ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май карары нигезендә гамәлдән чыгарыла, вазифалары *Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгына* тапшырыла.

Рәисләре: Ф.Г.Газизуллин (1991–96), И.Б.Фәттахов (1996–98), Д.М.Бикбов (1998–99), В.П.Васильев (1999–2001).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘ́Т МӨЛКӘТЕ́Н ХОСУСЫЙЛАШТЫРУ́ ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**. ТР Дәүләт Советының 1995 ел 22 июнь карары нигезендә оештырыла. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруны оештыра һәм аның барышына күзәтчелек итә, икътисад өлкәсендә монополияне чикләү чараларын үткәрә.Үз эченә җитештерү өлкәсенә караган пр-тиеләрне хосусыйлаштыру, агросәнәгать комплексы пр-тиеләрен хосусыйлаштыру, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалыгы пр-тиеләрен һәм торакны хосусыйлаштыру, икътисад, хокук, методик һәм оештыру эшләре идарәләрен; җитештерү өлкәсенә карамаган пр-тиеләрне хосусыйлаштыру, җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру бүлекләрен ала. ТР Президентына, ТР МКна һәм РФнең Дәүләт мөлкәте б-н идарә итү Дәүләт ком-тына буйсына. ТР Дәүләт Советының 1996 ел 27 ноябрь карары б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары *Татарстан Республикасының Дәүләт мөлкәте белән идарә итү дәүләт комитетына* тапшырыла.

Рәисләре: Д.М.Бикбов (1995–96), Р.Ш.Гобәйдуллин (1996). *Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘ́Т МУЗЕ́Е**, к. *Татарстан Республикасының милли музее*.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘ́Т СИ́МВОЛЛАРЫ**, дәүләтчелекне, халыкның милли үзенчәлекләрен һәм традицияләрен чагылдырган билгеләр: герб, флаг һәм гимн. К. *Татарстан Республикасы Дәүләт гербы, Татарстан Республикасы Дәүләт гимны, Татарстан Республикасы Дәүләт флагы*.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘ́Т СИМФО́НИК ОРКЕ́СТРЫ**. 1966 елда, нигездә, Казан консерваториясен тәмамлаучылардан оеша. Оештыручысы һәм беренче сәнгать җитәкчесе — Н.Рахлин (1966–78), аннан соңгы елларда оркестр б-н Р.Салаватов (1979–85), Ф.Мансуров (1986–2010), 2010 нан А.Сладковский җитәкчелек итә. Оркестр б-н дирижёрлар Р.Мартынов, С.Калагин, И.Коциныш, Р.Скуратов, Р.Җәләй һ.б. эшли. Коллектив танылган солистлар һәм дирижёрлар б-н даими хезмәттәшлек итә. Оркестрның концерт программаларында Н.Петров, В.Виардо, И.Ойстрах, В.Третьяков, М.Плетнёв, О.Каган, В.Спиваков, Л.Берман, Д.Шафран, М.Ростропович, Э.Вирсаладзе, Н.Гутман, В.Репин, И.Архипова, М.Бишу һ.б. чыгыш ясый. Репертуарын иң яхшы Көнбатыш Европа һәм рус симфонизмы әсәрләре, ш.у. хәзерге заман композиторларының муз. әсәрләре тәшкил итә. Музыкантлар татар симф. музыкасын актив пропагандалый. Коллективның концерт эшчәнлегендә абонемент концерт цикллары (ш.и. балалар һәм яшүсмерләр өчен дә) аерым игътибарга лаек. Югары профессиональлек, әчтәлекнең тирән ачылышы, тәэсирлелек, күзгә бәрелеп торган образлылык, төсмерләр байлыгы, башкарыла торган әсәрләрнең сәнгатьчә югарылыкта бирелеше коллективның иҗат йөзен билгели. Оркестр тарафыннан оештырылган халыкара «Рахлин сезоннары» («Рахлинские сезоны»), «Ак сирень» («Белая сирень»), «Казан көзе» («Казанская осень»), «Конкордия», «Денис Мацуев дуслары янында» («Денис Мацуев у друзей») музыка фестивальләре Татарстан һәм Россиянең мәдәни тормышында иң истәлекле вакыйгалар буларак кабул ителә. Ул ш.у. музыка мәктәпләрендә һәм консерваторияләрендә белем алучы сәләтле яшьләр өчен — «Республика казанышлары» проектын, гарип һәм каты авыру балалар өчен «Музыка белән дәвалану» («Исцеление музыкой») циклын оештыра. Оркестр еш кына П.И.Чайковский (Воткинск ш.), М.И.Глинка исем. (Смоленск ш.), «Болдино көзе» («Болдинская осень», Түбән Новгород ш.), «Ак төннәр» («Белые ночи», С.-Петербург), «Европа-Азия» (Казан) музыка фестивальләрендә катнаша. Мәскәүнең иң яхшы концерт залларында даими рәвештә иҗади хисап тота. 2014, 2015 тә Петербург абонементы кысаларында Мария театрының концерт залында чыгыш ясый. Бөтенроссия (1975, 1984), Бөтенсоюз (1977) конкурслары лауреаты.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘ́Т СОРТ СЫНА́У ХЕЗМӘТЕ́**, а.х. культуралары сортларын дәүләт сынавы системасы, 1937 елда СССР Халык Комиссарлары Советы карары нигезендә Бөтенсоюз үсемлекчелек ин-тының сорт сынау челтәре урынына булдырыла. 1990 га кадәр СССР Дәүләт сорт сынау челтәренә керә. 1991 дән




ТРның Дәүләт симфоник оркестры.

РФ А.х. министрлыгы каршындагы РФ селекция казанышларын сынау һәм саклау буенча дәүләт комиссиясе составында. ТРның Дәүләт сорт сынау хезмәте респ-ка инспекторлыгы һәм 7 дәүләт сорт сынау участогыннан: 6 сы комплекслы, 1 се яшелчә участокларыннан тора. Алар барысы да элекке колхоз һәм совхозлардан арендага алынган җирләрдә урнашкан, һәрберсенең 100 *га* га кадәр сөрүлек җирләре бар. Яшелчә сорт сынау участогы 4 басулы, калганнары 8 басулы чәчү әйләнеше системасы буенча эшли. Хуҗалык итү тарихы документта теркәлгән терр-я буларак, Дәүләт сорт сынау участогы туфрак белеме һәм игенчелек өчен фәнни яктан әһәмияткә ия. Дәүләт сорт сынау участогы оештырылганнан бирле Казан ун-тының туфрак белеме каф. хезмәткәрләре туфракларга күзәтү алып баралар, аларның торышында уңай һәм тискәре тенденцияләрне ачыклыйлар. ТР Д.с.с.х.нең төп бурычы — бөртекле һәм яшелчә техник культура сортларына дәүләт сынавы уздыру. Дәүләт сорт сынавы үз эченә 2 төрне ала: конкурслы — дәүләт сорт сынау участокларында 50 $м^2$ мәйдандагы делянкаларда һәм җитештерүле — 2 *га* га кадәр делянкаларда. Дәүләт сынавы нәтиҗәләренә карап, сортларны респ-ка яисә аерым зоналар (Кама алды, Идел алды, Кама аръягы) буенча районлаштыралар. 1937–2000 дә Россия һәм чит ил селекциясенең 6,5 мең а.х. культурасы сортлары өйрәнелгән. ТРда бу чорда 138 а.х. культураларының 385 тән артык сорты районлаштырылган. Бөртеклеләрнең уңышы респ-каның дәүләт сорт сынау участогы буенча 2001–2003 тә 1 *га* дан уртача 47,7 шәр ц тәшкил итә. Дәүләт сорт сынау участогы белгечләре яңа сорт орлыклар үрчетүгә зур игътибар бирәләр, бу исә аларны җитештерүгә кертү темпларын сизелерлек тизләтә.

ТР Д.с.с.х. җитәкчеләре: Т.П.Привалов (1938–41), И.К.Вовченко (1941–43), Б.Н.Мамаев (1943–45), Ю.И.Куховаренко (1945–46), В.Я.Метельков (1946–63), Г.С.Егоров (1963–67), А.А.Җиһаншин (1967–2006), Я.С.Ибраһимов (2006–13), С.Л.Турнин (2013 тән).

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘ́Т СЫНЛЫ́ СӘНГА́ТЬ МУЗЕЕ́**. 1958 елда ТАССР Дәүләт музееның картиналар галереясын ТАССР Дәүләт Сынлы сәнгать музеена үзгәртү турында РСФСР Мәдәният министрлыгы боерыгы нигезендә ачыла. 1964 тә ТАССР МС карары нигезендә яңа музейга шәһәр үзәгендә архит-ра истәлеге — *Казан хәрби округы командующие йорты* бинасы тапшырыла. Реконструкция ясалганнан соң, анда ТР Д.с.с.м. урнаша (1967). Күп кенә башка билгеле музейлар кебек ул да шәхси тупланма нигезендә оеша. Аның нигезен галим археолог һәм коллекционер А.Ф.Лихачёв тупланмасы тәшкил итә. Галим үлгәннән соң, аның абыйсы вице-адмирал И.Ф.Лихачёв тупланманы Казан шәһәренә бүләк итә (1891). Нәкышь сәнгате бүлегендә 425 картина исәпләнә, аларның күпчелеген Көнбатыш Европа: Фландрия, Голландия, Франция, Италия рәссамнары әсәрләре тәшкил итә. Тупланманың «рус» өлешенә караган 98 картинаның күпчелеге — Лихачёвның таныш һәм дус рәссамнары В.Г.Худяков, И.И.Шишкин, В.Г.Перов, Л.Л.Каменев, А.В.Гине әсәрләре. Башка танылган рус рәссамнары Д.Г.Левицкий, В.А.Тропинин, Л.К.Плахов, В.М.Резанов картиналары да бар. Шәһәр музее ачылган елдан (1895) аның сәнгать бүлеге тарихы да башланып китә.

Башта сәнгать коллекцияләре әкрен туплана, Окт. рев-циясеннән соң национализацияләнгән утар һәм йортларның, бетерелгән чиркәү һәм монастырьларның сәнгать әсәрләре, ш.у. дәүләт музей фондын өләшү, картиналарны музей саклагычларыннан бүлеп бирү хисабына планлы рәвештә тулыландыру башлана. 1920–30 да музейга берьюлы унлап, кайвакыт йөздән артык сәнгать әсәре тапшырыла. Алар арасында искиткеч борынгы рус нәкышь, гамәли-бизәлеш сәнгате үрнәкләре: фарфор, пыяла һәм металлдан сәнгать эшләнмәләре, укалап чигелгән челтәр, чигелгән әйберләр, В.Д.Поленов, В.В.Пукирев, Н.В.Неврев, И.К.Айвазовский, И.И.Шишкин, А.К.Саврасов, Ф.А.Васильев, В.Е.Маковский, В.Г.Перов, И.Н.Крамский, И.Е.Репин, И.И.Левитан, В.А.Серов, К.А.Коровин һ.б.ның картиналары бар. Коллекциянең шундый тиз арада тулылануы бүлек эшен үзгәртергә мөмкинлек бирә. Яңартуны башлап җибәрүчеләр — 1919 да музейның сәнгать бүлеге мөдире итеп билгеләнгән, сәнгать белгече һәм рәссам П.М.*Дульский* һәм аның укучысы, сәнгать тарихчысы П.Е.*Корнилов*. Аларның тырышлыгы б-н бүлекнең статусы ТАССР Үзәк музееның картиналар галереясы дип үзгәртелә, экспозицияләр мәйданы арттырыла, яңа бүлекләр, ш.и. борынгы рус сәнгате бүлеге, гравюралар кабинеты булдырыла, күргәзмәләр эше, нәшрият эш-



ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.







ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее заллары.

чәнлеге җәелдереп җибәрелә. Дульскийның казанышы — җирле рәссамнарның әсәрләре фондын оештыру. 1919 да ул музей өчен Н.И.Фешинның берничә картинасын сатып ала. Картиналар Казан рәссамнарының коллекциясен башлап җибәрәләр. Соңрак ул П.П.Беньков, Г.А.Медведев, П.А.Радимов, В.К.Тимофеев, Б.И.Урманче, К.К.Чеботарёв, Н.С.Шикалов һ.б. осталарның әсәрләре б-н тулылана. 1932 дән картиналар галереясында әйдәп баручы бүлекләр, аеруча рус сәнгате бүлеге экспозицияләре тарихи принцип буенча төзелә башлый. Халык сәнгате әсәрләрен җыю буенча экспедицияләр, РСФСР һәм ТАССР Мәдәният министрлыкларының, музейның үзенең әсәрләрне сатып алулары, аерым кешеләрнең бүләкләре сугыштан соңгы елларда фондларны тулыландыручы төп чыганакларга әйләнәләр. Экспозицияләр урта гасырлардан алып бүгенге көннәргә кадәр сәнгать үсеше процессын эзлекле рәвештә ачып күрсәтә. Ташландык хәлдә булган музей паркы реконструкцияләнә, аны ачык һава астында урнашкан скульптура күргәзмәсе бизи. Анда иҗтимагый чаралар (фотоклуб утырышлары һ.б.) уздырыла башлый. 1996 да яңа, махсус проектлаштырылган музей корпусы сафка баса, анда депозитарий һәм 3 күргәзмә залы урнаша.

ТР Д.с.с.м. – РФнең иң зур сәнгать музейларыннан берсе. Аның гомуми мәйданы 15067,5 *м*² (ш.и. экспозицияләр мәйданы 6447,1 *м*², саклау урынының мәйданы 1148,4 *м*²), музей паркы мәйданы 1800,7 *м*². Фондларында 25 меңнән артык нәкышь, скульптура, графика, гамәли бизәлеш сәнгате әсәрләре саклана. Музейның төп экспозиция бүлекләре — борынгы рус, рус, Көнбатыш Европа сәнгате бүлекләре. Музей тупланмасында уникаль коллекцияләр, ш.и. 39 нәкышь әсәреннән һәм 359 график эштән — рәсемнәрдән, офортлардан, ташбасмалардан торган Алабуга шәһәрендә туган И.И.Шишкин коллекциясе; 90 нәкышь әсәрен һәм 86 график эшне, берничә дистә гамәли-бизәлеш сәнгате предметын эченә алган, илебездә иң зур саналган Н.И.Фешин әсәрләре коллекциясе; 11 меңнән артык проф. һәм халык сәнгате әсәрләрен эченә алган Татарстан осталары хезмәтләре коллекциясе бар. Алар арасында – өлкән буын татар рәссамнары Х.Г.Якупов, Л.Г.Фәттахов, М.Г.Усманов, Г.Г.Рахманкулова, графиклар Э.Г.Ситдыйков, И.К.Әхмәдиев, Э.Я.Зарипов, скульпторлар Б.И.Урманче, В.М.Маликов, А.Х.Әбдрәшитов, Н.И.Гаделев, Ә.К.Бәширов әсәрләре. А.Ә.Абызгилдин, З.Ф.Гыймаев, И.К.Зарипов, Е.В.Зуев, Р.Ә.Килдебәков, В.Н.Скобеев, Ш.М.Шәйдуллин, В.К.Фёдоров, И.Л.Языинин, С.М.Кульбака, И.К.Колмогорцева, В.В.Карамышев, В.А.Попов, Л.А.Потягунин, Л.М.Кальюранд, Т.А.Зуева, Б.И.Майоров һәм күп кенә башка осталарның әсәрләре тәкъдим ителә. ТР Д.с.с.м.нда В.П.Аршинов, Н.У.Әлмиев, Е.Г.Голубцов, И.М.Ханов кебек поставангард юнәлешендәге рәссамнарның, ш.у. яңа иҗади берләшмәләр һәм төркемнәр әгъзаларының картиналары саклана (к. *Сынлы сәнгать*).

2005 тә музейга, аның ф-лы — милли сәнгать галереясын урнаштыру өчен, Казан кремлендәге элекке юнкерлар уч-щесе бинасының заллары бирелә. Анда Казан губернасы сәнгать әсәрләре һәм татар сәнгате бүлеге күчерелә. Җитәкчеләре арасында: В.М.Дьяконов (1958–62), Г.А.Могильникова (1962–68), Ю.И.Петров (1968–83), А.А.Сластунин (1989–2006), Р.М.Нургалиева (2006 дан).

*Әд.:* Каталог художественной галереи. К., 1952; Художественная галерея: Живопись. Графика. Скульптура. К., 1956; Художественные сокровища Татарстана: собрание альбомов-каталогов в 7 т. К., 2013; Государственный музей изобразительных искусств Республики Татарстан. К., 1997; Государственный музей изобразительных искусств Республики Татарстан, г.Казань: Альбом. М., 2002; Государственный музей изобразительных искусств Республики Татарстан: Русское искусство XVII — начала XX веков. Живопись: Каталог. К., 2005.

*А.И.Новицкий.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘ́Т ФИЛАРМО́НИЯСЕ**, к. *Татар филармониясе.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘ́Т ФОЛЬКЛО́Р МУ́ЗЫКАСЫ АНСА́МБЛЕ**. 1999 елда Татар филармониясе каршында оеша. Коллектив эшчәнлегенең максаты — татар халкының муз. мирасын сәнгатьнең заманча формалары аша саклау, баету, пропагандалау. Репертуарының нигезен татарларның төрле этник төркемнәренә караган, театральләштерелгән тамашалар рәвешендә тәкъдим ителгән аз билгеле, сирәк башкарыла торган фольклор иҗаты (йола җырлары, вокаль һәм инструменталь музыка, биюләр) тәшкил итә. Коллектив Россиядә һәм чит илдә актив концерт эшчәнлеге алып бара. Ансамбльгә нигез салучыларның берсе — И.Шакиров, беренче сәнгать җитәкчеләре — Р.Гыйләҗев, М.Яхъяев; 2002 дән — А.Фәйзрахманов. Хормейстеры — К.Костылова, балетмейстеры — С.Фәйзуллина, музыка җитәкчесе — И.Фәйзетдинов. Ансамбль — бөтенроссия һәм халыкара конкурслар лауреаты.

*Әд.:* Татарская государственная филармония им. Габдуллы Тукая (1937–2007). К., 2007.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘ́Т ХАЛЫ́К МУ́ЗЫКА УЕ́Н КОРАЛЛАРЫ́ ОРКЕ́СТРЫ**, 1993 елда Казан консерваториясенең халык музыка уен кораллары оркестры җирлегендә оеша. Оештыручысы һәм сәнгать җитәкчесе — А.И.Шутиков. Оркестрның киң, күпкыр-



ТРның Дәүләт фольклор музыкасы ансамбле.



ТРның Дәүләт халык музыка уен кораллары оркестры.

лы, даими рәвештә яңартылып торган репертуарын рус һәм чит ил классикларының иң яхшы муз. әсәрләре, халык көйләренең оригиналь эшкәртмәләре тәшкил итә. Татар халык һәм композиторлар көйләре дә репертуарында төп урыннарның берсен алып тора. С.Сәйдәшев, Ә.Бакиров, Р.Яхин, Ф.Әхмәтов кебек композиторларның иҗатларына багышланган монографик концертлар уздырыла. Ф.Яруллин, М.Мозаффаров, А.Ключарёв, Н.Җиһанов, А.Монасыйпов, Р.Еникиев һ.б.ның муз. әсәрләре башкарыла. Оркестр Татарстан, Россиянең башка респ-ка һәм өлкәләре, БДБ илләренең танылган җырчылары (И.Шакиров, Р.Ибраһимов, З.Сөнгатуллина, В.Ганиева, А.Соловьяненко, А.Эйзен, Л.Рюмина, А.Ведерников, А.Стрельченко, З.Соткилава, А.Днишев һ.б.) б-н хезмәттәшлек итә. Коллективның иҗат эшчәнлегендәге мөһим юнәлешләреннән берсе — абонемент концертлары, ш.и. балалар һәм яшүсмерләр өчен «Тыңла һәм бел» («Послушай и узнай»), «Маэстроның тылсымлы таякчыгы артыннан» («Вслед за волшебной палочкой маэстро»), «Музыка көзгесендә әдәбият» («Литература в зеркале Музыки»), «Мальвинаның музыка әлифбасы» («Музыкальный букварь Мальвины»), «Музыкаль тартма хәзинәләре» («Сокровища музыкальной шкатулки») һ.б. Югары башкару культурасы, инструменталь төркемнәрнең тотрыклылыгы, техник чарланганлык, башкарыла торган әсәрнең формасын һәм стилен яхшы тоеп эш итү коллективның иҗади йөзен билгели. Оркестр даими рәвештә Россия һәм Татарстан шәһәрләрендә, чит илләрдә (Австрия, Германия, Голландия) концертлар бирә, радио һәм телевидениедә чыгышлар ясый. Коллектив тарафыннан әзерләп башкарылган концерт программаларының саны 100 дән арта.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ЖУРНАЛИСТЛА́Р БЕРЛЕГЕ́**, матбугат, телевидение, китап нәшрияты, мәгълүмат агентлыклары хезмәткәрләренең иҗади берләшмәсе. Казан һәм губерна совет журналистлары берлегенең оештырылуы 1918 елның 21 декабрендә «Знамя революции» г-тасы редакциясендәге җыелышта игълан ителә (уставы 1918 нең 26 декабрендә Мәскәүдә журналистларның II Бөтенроссия съездында раслана). 1919 да Казан һәм губерна журналистларының коммунистик берлеге итеп үзгәртелә, 1920 дә Матбугат хезмәткәрләре берлеге итеп үзгәртеп корыла. 1957 нең июлендә ТАССР Журналистлар берлеге оештырыла, 1992 дә уставы кабул ителә, аның нигезендә берлек ТРның проф. иҗади оешмасы буларак раслана. 1998 дән — «Иҗади берлек — ТР Журналистлар берлеге» иҗтимагый оешмасы. Берлекнең максаты — журналист этикасының үтәлүенә булышлык итү, журналистлар һәм гаммәви мәгълүмат чараларын хокукый яклауны ныгыту. Оешма б-н төрле елларда журналистлар Г.М.*Рябков* (1957–59), Ш.Х.*Хамматов* (1959–83), Р.М.*Сабиров* (1983–84), И.К.*Хәйруллин* (1984–90), Ш.Ш.*Хамматов* (1990–95) җитәкчелек итә, 1995 тән ТР Журналистлар берлеген Р.А.*Ратникова* җитәкли. 2015 тә оешмада 1229 әгъза исәпләнә, Татарстанда 50 терр. бүлек эшләп килә. Берлек әгъзалары арасында күренекле чит ил журналистлары һәм җәмәгать эшлеклеләре Г.Акыш (Төркия), М.Ерзин (Казакъстан), М.Хотопп (Германия) һ.б. ТР Журналистлар берлегенең башлангыч оешмалары иҗат коллективларында, журналистлар берләшмәләрендә эшли. Берлек булышлыгы б-н һәр елны *«Бәллүр каләм — Хрустальное перо»*, «Алтын каләм — Золотое перо» конкурслары уздырыла.

*Әд.:* Насыров Т. Начнём сначала // Респ. Татарстан. 1998. 1 мая; Лебедев А.А. Шагаем нога в ногу уже девяносто лет // Респ. Татарстан. 2008. 26 дек.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ЖУРНАЛИСТЛА́Р БЕРЛЕГЕ́ БҮЛӘКЛӘРЕ́**, Х.Ямашев исемендәге респ-ка бүләге, 1971 елның декабрендә ТАССР Журналистлар берлеге идарәсе тарафыннан булдырыла. Журналистлык осталыгына, темасының актуальлегенә, иҗтимагый әһәмиятенә карап, матбугатта басылган иң яхшы иҗтимагый язмалар, теле- һәм радиотапшырулар өчен ел саен бирелә. 1972–91 елларда әлеге бүләккә 63 журналист лаек була. 1992–97 дә ТР Журналистлар берлеге бүләкләре дип үзгәртелә (16 лауреат). 1998 дән «Бәллүр каләм — Хрустальное перо» бүләге тапшырыла. 1998–2015 тә 14 номинация буенча бирелә. Бу чорда «Хөрмәт һәм ихтирам», «Журналистикада исем», «Иң яхшы район (шәһәр) газетасы», «Темасы — җирле, осталыгы — башкаланыкы», «Китап авторы — журналист», «Корпоратив басма», «Ел дебюты» һ.б. номинацияләрдә 300 дән артык журналист һәм журналистлар коллективы лауреат була; «Туган тел» номинациясендә — Россиянең һәм чит илләрнең татар телле басмалары журналистлары; «Ел министры», «Елның төбәк лидеры», «Ел эшмәкәре», «Ел меценаты», «Ел медиа-персонасы», «Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм иҗтимагый оешмалар б-н нәтиҗәле элемтә өчен» һ.б. номинацияләрдә респ-ка министрлыклары һәм ведомстволары, сәнәгать пр-тиеләре җитәкчеләре, хакимият башлыклары, эшмәкәрләр, меценатлар лауреат исемен ала.

*Ю.М.Ханжин.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ҖИР РЕСУ́РСЛАРЫ ҺӘМ ҖИР РЕФО́РМАСЫ ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**. ТССР ЮСның 1991 ел 7 февраль карары нигезендә оештырыла. Җир мөнәсәбәтләре һәм җир ресурсларын куллану мәсьәләләре буенча көйләү, тармакара килештерү эшләрен башкара. Гомуми, җир төзелеше һәм җирләрне яңадан бүлү, дәүләт җир кадастры һәм җир мониторингы, мәгълүмат һәм программа б-н тәэмин итү, җирләрне куллану һәм саклауда дәүләт контроле, бухгалтерлык исәбе, хисап тоту һәм финанс тәэминаты бүлекләрен берләштерә. Дәүләт ком-ты системасына җир ресурслары һәм җир реформасы буенча 43 район һәм шәһәр ком-ты, Респ-ка җир-кадастр үзәге керә. ТР Президентына, ТР МКна (1994 кә кадәр РФ Хөкүмәте каршындагы шул юнәлештәге ком-тка) буйсына. ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май карары нигезендә гамәлдән чыгарыла, вазифалары Татарстан Респ-касының Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгына тапшырыла. Рәисе — А.А.Ефремов (1991–2001).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТИ́ МӨНӘСӘБӘТЛӘ́Р МИНИ́СТРЛЫГЫ**, ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май һәм ТР МКның 2001 ел 9 июль карарлары б-н *Татарстан Республикасының Дәүләт мөлкәте белән идарә итү дәүләт комитеты* һәм *Татарстан Республикасының Җир ресурслары һәм җир реформасы дәүләт комитеты* җирлегендә оештырыла. Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсен-

дә дәүләт сәясәтен, ш.и. хосусыйлаштыруны, дәүләт мөлкәте һәм җир ресурслары б-н идарә итүне гамәлгә ашыра. Мөлкәти мөнәсәбәтләр икътисады һәм үсеше (мөлкәти мөнәсәбәтләр икътисади анализы һәм үсеше, базар инфраструктурасын бәяләү һәм көйләү бүлекләре), исәп-хисап һәм мәгълүмат-аналитика эше (мәгълүмат-аналитика, исәп-хисап, мәгълүматлаштыру бүлекләре), күчемсез милек (аренда, дәүләт мөлкәтен файдалануны контрольдә тоту, реализация бүлекләре), хосусыйлаштыру һәм АҖләр эшчәнлеген көйләү (дәүләт унитар пр-тиеләрен хосусыйлаштыру һәм реформалаштыру, милекнең чикләрен билгеләү, җир арендасы мөнәсәбәтләрен көйләү, җирне хосусыйлаштыру һәм аның б-н идарә итү, корпоратив идарә, фондлар базары бүлекләре), хокук (методология, дәүләтнең мөлкәти мәнфәгатьләрен яклау, җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләрне хокукый тәэмин итү бүлекләре), эшләр башкару (кадрлар һәм оештыру эше бүлеге, хуҗалык часте, канцелярия, архив, машбюро) идарәләрен, режимлы-яшерен хезмәтне, финанс бүлеген һ.б.ны үз эченә ала. Министрлык системасына дәүләт унитар пр-тиесе, җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр терр. органнары керә. ТР Президентына һәм МКна буйсына.

Министрлар: В.П.Васильев (2001–09), А.К.Хамаев (2009дан).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ЗУР КОНЦЕ́РТ ЗАЛЫ́**, С. Сәйдәшев исемендә. Казан консерваториясенең Актлар залы бинасыннан (арх. М.Х.Агишев, 1967) арх. Е.И.Прокофьев һәм В.П.Логинов проекты буенча 1994–96 елларда реконструкцияләнә. Ирек мәйданында урнашкан. Симметрик композицияле ике катлы монументаль бина. Төп фасадны зур колонналар б-н рустланган тирән портик ачып тора. Бинаның төп ишеге портикның үзәгендә, хезмәткәрләр өчен уелган ишекләр ишегалды ягында урнашкан. Фасадлар бизәлеше катлар һәм өске кәрнизләр арасындагы горизонтальлекнең аттик парапетлар һәм өчпочмак булып очланган тәрәзәләр б-н ритмик турыпочмаклы вертикальләрнең контрастлыгына корылган. Төп фасадның үзәге ике кыеклы түбә б-н ябылган тирән куыш б-н ачылып китә. 1 нче катта — вестибюль, гардероб һәм эш бүлмәләре урнашкан. Бинада репетицияләр залы һәм артистлар бүлмәләре бар. Ике мәр-



ТРның С.Сәйдәшев исем. Зур концерт залы. Казан. Архитекторлары Е.И.Прокофьев, В.П.Логинов. 1994–96.



ТРның С.Сәйдәшев исем. Зур концерт залы. Казан. Төп зал интерьеры.

мәр баскыч 2 нче каттагы фойега һәм кече залга алып менә. Планда трапеция рәвешендәге залда партердан соң арткы дивар буенда тамашачылар өчен зур булмаган амфитеатры бар, аның өстендә балкон урнашкан. Зур залның акустик мөмкинлекләре «Acoustic Dimensions» инглиз компаниясе белгечләре тарафыннан билгеләнә: ул җырларны аерым һәм хор б-н башкару, камера һәм симфоник оркестрлар, 30 регистрлы орган яңгырашына исәпләнгән. 1997 дә Голландия «Flentop» фирмасының Зур органы урнаштырыла. Зал түшәмәсе мәрмәреннән эшләнгән плитәләр һәм акустик агач панельләр, яссы бетон түшәме татар халык орнаментлары файдаланылган дивар нәкыше б-н бизәлгән. Кече камера музыкасы залы классик стильдә. Түшәм кессон б-н эшләнгән һәм агач б-н тышланган, диварлар итальян мәрмәре б-н тышланган һәм татар милли мотивларына нигезләнеп, алтын йөгертелгән агач детальләр б-н бизәлгән, люстралары — Богемия бәллүреннән. ТР З.к.з., нигездә, неоклассицизм стилендә төзелгән. Фойе интерьерларын күренекле композиторларның мәрмәр бюстлары бизәп тора. 2001 елның февралендә ТР З.к.з.на С.Сәйдәшев исеме бирелә. Реконструкция авторлары РФнең Дәүләт бүләгенә лаек була (2000).

*Х.Г.Надыйрова.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ИКЪТИСАДИ́ РАЙОННАРЫ́**, табигый һәм икътисади шартларының үзенчәлекләре, хуҗалыгының географик хезмәт бүленеше нигезендә махсуслашуы, тотрыклы эчке бәйләнешләре булу б-н башкалардан аерылып торучы терр-я. Икътисади районлаштыруның төп максаты — терр. көйләү өчен иң уңай шартлар тудыру, региональ социаль-икътисади сәясәтне фаразлау һәм гамәлгә ашыру. ТРда 2007 елга кадәр 6 икътисади район билгеләнеп йөртелә: Көнбатыш Кама аръягы, Казан, Идел алды, Кама алды, Төньяк-Көнчыгыш Кама буе, Көньяк-Көнчыгыш Кама аръягы. 2008 дә, Россия үсешенең озак сроклы стратегиясенең состав өлеше булган «Татарстан Республикасының җитештерү көчләрен кластерлау нигезендә 2020 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге вакытка үстерү һәм урнаштыру» программасы кысаларында яңа икътисади районлаштыру үткәрелә. 7 икътисади район формалаштырыла: Башкала (Казан ш., Әтнә, Югары Ослан, Биектау, Яшел Үзән, Лаеш һәм Питрәч р-ннары), Көнбатыш (Апас, Буа, Чүпрәле, Кайбыч, Кама Тамагы, Тәтеш), Төньяк (Арча, Балтач, Кукмара, Мамадыш, Балык Бистәсе, Саба, Теләче), Көньяк (Аксубай, Алексеев, Әлки, Яңа Чишмә, Нурлат, Спас, Чистай), Кама (Алабуга, Зәй, Менделеев, Түбән Кама, Тукай р-ннары, Чаллы ш.), Нефть (Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Сарман, Чирмешән), Көнчыгыш (Әгерҗе, Азнакай, Актаныш, Баулы, Минзәлә, Мөслим, Ютазы). ТР И.р.н билгеләгәндә халыкның тормыш дәрәҗәсе, шәхси керемнәр б-н тәэмин ителеше, хезмәт хакы, эшсезлек дәрәҗәсе, торак б-н тәэмин ителеше һ.б. социаль-икътисади күрсәткечләр исәпкә алына.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ КИНЕМАТОГРА́ФИЯ ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**. ТССР МСның 1991 ел 30 гыйнвар карары нигезендә ТССР Дәүләт кинематографияне үстерү фонды буларак оеша, ТР ЮСның 1993 ел 4 март карары б-н ТР К.д.к.на үзгәртелә. Кинематография өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыра, кинематография үсешен хокукый, икътисади һәм матди-техник яктан тәэмин итә. ТР К.д.к. системасын Казан кинохроника студиясе, «Татаркиновидеопрокат», «Киносервис», «Татарвидеофильм» җитештерү берләшмәләре, «Татарфильм» киностудиясе, кинокомбинат, шәһәр һәм район киночелтәрләре, кинотеатрлар, ТРның Кинематография дәүләт оркестры, Респ-ка кино сәнгате йорты тәшкил итә. Ком-т ТР Президентына, ТР МКна һәм РФнең шундый ук дәүләт ком-тына буйсына. ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май карары нигезендә гамәлдән чыгарыла. Вазифалары *Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына* тапшырыла.

Рәисләре: Р.С.Насыйбуллин (1993–95), З.Г.Бохараев (1995–2001).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ КОМПОЗИ́ТОРЛАР БЕРЛЕГЕ́** (ТР КБ), профессиональ композиторлар һәм музыка белгечләренең иҗади җәмәгать оешмасы. 1939 елда нигез салына. Берлекнең төп максатлары — респ-ка халыкларының муз. һәм рухи мәдәниятләрен үстерү һәм баету; төрле жанрдагы муз. әсәрләр иҗат итү өчен шартлар тудыру; муз. иҗат һәм музыка сәнгатенең аеруча мөһим күренешләренең үсеш процессларын фәнни үзләштерү, аны пропагандалау; концерт, фестиваль, конкурс, конференцияләр уздыру. Югары җитәкче орган булып 5 елга 1 тапкыр чакырыла торган съезд тора, башкарма орган — рәис җитәкчелегендәге идарә. ТР КБ әгъзаларының (секция әгъзаларының) ай саен була торган җыелышларында композиторларның яңа әсәрләре (яздырылган рәвештә һәм башкару аша), музыка белгечләренең хезмәтләре тыңлана һәм алар буенча фикер алышулар була. Чираттагы 13 нче съезд (2014 нең 8–10 декабре) оешма төзелүнең 75 еллыгына багышлана. 2015 нең 1 гыйнварына ТР КБндә 53 әгъза исәпләнә (36 комп., 17 музыка белгече).

ТР КБ тарафыннан даими уздырыла торган аеруча әһәмиятле чаралар — Халыкара «*Европа-Азия*» заманча музыка фестивале (1993 тән), *Идел-Урал буе Республикалары композиторларының музыка фестивале*



ТАССРның композиторлар берлеге. Утырып торалар (сулдан уңга): Ю.Виноградов, Н.Җиһанов, С.Сәйдәшев, С.Мозаффаров, А.Ключарёв. Басып торалар: А.Рыжкин, Х.Вәлиуллин, А.Леман, З.Хәбибуллин, Җ.Фәйзи. Казан. 1948.

(1982 дән), «Muz-Tranzit» фестивале, Татарстан композиторларының яңа әсәрләреннән төзелгән «Фоат Мансуров белән премьералар» симф. концертлары, респ-ка композиторларының ел саен була торган юбилей концертлары (симф., камера, хор концертлары). 20 йөзнең соңгы унъеллыгында Берлек составындагы композиторларның халыкара эшчәнлеге киң үсеш ала. Дөньяның төрле илләрендә яшәп иҗат итүче композиторлар б-н элемтәләр урнаштыру беренче чиратта Татарстан композиторлары музыкасын киң пропагандалауга, дөнья музыка сөючеләр җәмәгатьчелегенең игътибарын респ-каның мәдәни казанышларына юнәлдерүгә хезмәт итә. Gaudeamus Fondation заманча музыка үзәге (Амстердам, Нидерландия) б-н хезмәттәшлек итә. Оешманың Халыкара заманча музыка җәмгыятенә кабул ителүе (1999) әлеге элемтәләрнең нәтиҗәсе булып тора. ТР КБ эшчәнлеге София Гобәйдуллинаның махсуслаштырылган Заманча музыка үзәге аша да алып барыла, ул хәзерге заман композиторлары музее булу б-н бергә заманча музыканы пропагандалау үзәге эшләрен дә алып бара. Берлек каршында муз. һәм әдәби клублар, Казанның музыка һәм сәнгать мәктәпләре б-н берлектә фестивальләр һәм иҗади очрашулар, яшь композиторларның әсәрләреннән торган концертлар уздыручы яшьләр клубы эшли. ТР КБ урнашкан бина архит-ра истәлеге булып тора (М.И.Подуруева йорты, 1906, арх. Ф.Р.Амлонг).

Идарә рәисләре: Н.Г.*Җиһанов* (1939–77), М.З.*Яруллин* (1977–89), Р.Ф.*Кәлимуллин* (1989 дан).

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ КУЛЛАНУЧЫЛА́Р ХОКУКЛАРЫ́Н ЯКЛА́У ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**. ТР МКның 1995 ел 22 сентябрь һәм ТР Дәүләт Советының 1996 ел 22 июнь карарлары нигезендә оештырыла. Кулланучылар хокуклары, кече эшмәкәрлекне яклау һәм үстерү, товарлар сыйфатын сертификацияләү, күзәтчелек, лицензияләү, бәяләр билгеләү, интеллектуаль милекне яклау, иминият, стандартлаштыру һәм метрология, инвестицияләр, кыйммәтле кәгазьләр базары, товар биржалары, технологияләр кертү, прогнозлау өлкәсендә җитәкчелек итә, килештерү һәм көйләү эшләрен гамәлгә ашыра. Сертификацияләү һәм бәйсез кулланучылар экспертизасы, лицензияләү, бәяләр, кулланучылар хокукларын яклау буенча инспекция — контроль һәм яңа икътисади структуралар идарәләрен; дәүләт транспорт, алкоголь продукциясенә дәүләт монополиясе инспекцияләрен үз эченә ала. ТР Президентына һәм ТР МКна буйсына. ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май карары нигезендә гамәлдән чыгарыла, вазифалары *Татарстан Республикасы Сәүдә һәм тышкы икътисади хезмәттәшлек министрлыгына* тапшырыла. Рәисе — В.Н.Михайлов (1995–2001).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ МАКТА́У ГРА́МОТАСЫ**, дәүләт бүләге. ТАССР ЮС Президиумының 1940 ел 1 февраль Указы б-н ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы буларак булдырыла. ТР ЮСның 1992 ел 7 февраль карары б-н ТРның Мактау грамотасы итеп үзгәртелә. ТР Президенты (1992 елга кадәр — ТАССР,ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан җитештерүнең нәтиҗәлелеген күтәрүдәге югары күрсәткечләр, күрсәтелгән хезмәт һәм җитештерелгән продукциянең сыйфатын яхшырту, житештерү, фәнни һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлектә, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, сәнгать һәм әдәбият, физик культура һәм спорт өлкәсендә ирешкән казанышлар, дәүләти, икътисади, социаль һәм мәдәни төзелештәге уңышлар, хокук тәртибе, халыклар арасында тынычлык һәм дуслыкны ныгытудагы хезмәтләр өчен бирелә.ТРның 2011 ел 10 октябрь Законы б-н гамәлдән чыгарыла. 2008 нең 1 гыйнварына ТР М.г.на 401 коллектив,7654 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ МАКТАУЛЫ́ ИСЕМНӘРЕ́**, гражданнарның хезмәттә ирешкән казанышларын тануның бер формасы. 1995 елдан ТР Дәүләт Советы (1992 гә кадәр ТАССР, ТССР ЮСлары Президиумы, 1992 — 95 тә ТР ЮС) билгели. 1991 дән ТР Президенты (элек ТАССР, ТССР ЮСлары Президиумы) тарафыннан бирелә. Татарстанда халык артисты (1940 та гамәлгә кертелә), халык рәссамы (1948), халык язучысы (1985), халык шагыйре (1985), халык укытучысы (2004); атказ. а.х. механизаторы (1961), атказ. а.х. хезмәткәре (1985), атказ. агроном (1954), атказ. азык-төлек сәнәгате хезмәткәре (1984), атказ. артист (1940), атказ. архитектор (1983), атказ. вет. табибе (1954), атказ. газ сәнәгате хезмәткәре (2012), атказ. геолог (1986), атказ. җиңел сәнәгать хезмәткәре (1984), атказ. җир төзүче (1995), атказ. зоотехник (1954), атказ. икътисадчы (1983), атказ. коткаручы (2004), атказ. матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре (2012), атказ. машина төзүче (1980), атказ. мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре (1982), атказ. мәдәният хезмәткәре (1965), атказ. мелиоратор (1976), атказ. нефтьче (1971), атказ. рационализатор (1985), атказ. сәнгать эшлеклесе (1940), атказ. сәламәтлек саклау хезмәткәре (1985), атказ. сәүдә хезмәткәре (1979–2004), атказ. табиб (1940), атказ. терлекче (1973), атказ. торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре (1978), атказ. төзүче (1960), атказ. транспорт хезмәткәре (1980), атказ. уйлап табучы (1985), атказ. укытучы (1940), атказ. урманчы (1967), атказ. фән эшлеклесе (1940), атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1940–2004); атказ. физик культура хезмәткәре (1983), атказ. халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре (1978–2004), атказ. халыкка хезмәт күрсәтү сферасы хезмәткәре (2004), атказ. халыкны социаль яклау хезмәткәре (2001), атказ. химик (1983), атказ. эколог (2004), атказ. энергетик (1979), атказ. эчке эшләр хезмәткәре (2000), атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2004), атказ. юрист (1984); атказ. яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәре (2015), ш.у. Татарстанның Социалистик Төзелеш Батыры (1931–35, ТАССР ҮБК тарафыннан бирелә), Хезмәт Батыры (1920 — 38, 1927 гә кадәр Татарстан Профсоюзлар өлкә советы, 1927 дән ТАССР ҮБК тарафыннан бирелә) дигән мактаулы исемнәр бар.

*Е.Б.Долгов.*

**«ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ МАТБУГА́Т ЕЛЪЯЗМАСЫ́»**, һәр квартал саен чыга торган дәүләт библиографик барлау-теркәү күрсәткече. 1930 елда ТАССРның Китап палатасы тарафыннан татар һәм рус телләрендә «Басма хезмәтләр елъязмасы» исеме б-н басыла башлый. Һәр ел саен аерым кисәкләр б-н 1938–61 елларда — «Китап елъязмасы», «Рецензияләр елъязмасы», «Газета-журнал мәкаләләре елъязмасы», «Вакытлы матбугат елъязмасы», 1961 дән — «ТАССРның матбугат елъязмасы», 1991 дән — хәзерге исеме б-н чыга. 2007 дән Татарстан Респ-касы Дәүләт матбугат архивы тарафыннан нәшер ителә. 1941 нең июленнән алып 1944 кә кадәр басылмый. 1941–45 елларга «Китап елъязмасы» 1973 тә төзелә һәм басыла. 1945–60 та татар һәм рус телләрендә дөнья күрә; 1961 дән һәр бүлек составында икетеллелек гамәлгә ашырыла. 2007 дән Татарстан Респ-касы Дәүләт матбугат архивы тарафыннан нәшер ителә. Бүлекләр: китап елъязмасы, сынлы сәнгать басмалары елъязмасы, ноталар елъязмасы, ТРның вакытлы матбугат һәм дәвамлы басмалар елъязмасы, библиографик кулланмалар күрсәткече, рецензияләр елъязмасы, газета һәм журнал язмалары елъязмасы, ТР башка респ-калар матбугатында. «Китап елъязмасы» бүлегендә ТР терр-ясендә чыга торган китаплар һәм брошюралар, ш.у. вакытлы һәм дәвамлы тупланмалар теркәлеп барыла, диссертация авторефератлары аерып бирелә.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ МӘГАРИ́Ф ҺӘМ ФӘН МИНИ́СТРЛЫГЫ**. Тарихы РСФСР Мәгариф Халык комис-тының 1918 ел 21 гыйнвар карары һәм Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна советы гомуми җыелышының 1918 ел 26 февраль карары нигезендә оештырылган Казан Совет Эшче-Крәстиян Респ-касы Мәгариф комис-тыннан башлана. Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советының 1918 ел 16 һәм 31 май карарлары һәм Казан губерна ХКСның 1918 ел 3 июнь карары б-н — Казан губерна халык мәгарифе комис-ты, Казан губерна халык мәгарифе бүлекләре советының 1918 ел 7 октябрь карары һәм Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары Казан губерна советы башкарма

ком-тының 1918 ел 15 октябрь карары б-н губерна башкарма ком-ты каршындагы халык мәгарифе бүлеге, БҮБК һәм РСФСР ХКСның 1920 ел 27 май Декреты һәм ТАССР ҮБКның 1920 ел 28 сентябрь карары б-н ТАССР Мәгариф халык комис-ты итеп үзгәртелә. Элек Халык комис-ты мәдәниятнең барлык тармаклары: мәктәп һәм мәктәпкәчә тәрбия эшләре, халык арасында сәяси-агарту эшләре, һөнәри-техник әзерлек, нәшриятлар эшчәнлеге, мәдәни-агарту учреждениеләре, театрлар, кино, музыка, сынлы сәнгать б-н; 1920 еллар уртасыннан — гомуми һәм һөнәри характердагы фәнни, уку-укыту, сәяси-агарту һәм сәнгать эшчәнлеге, фәнни, музей һәм сәнгать учреждениеләре б-н; 1930 еллар уртасыннан — фәкать халык мәгарифе б-н; 1936–45 тә халык мәгарифе һәм мәдәни-агарту эшләре б-н җитәкчелек итә. 1920 елларда — Оештыру үзәген (адм.-оештыру, стат., тәэминат, планлаштыру-финанс бүлекләре), *Академүзәкне* (гомуми канцелярия; архив идарәсе; тәрҗемә, фәнни секторлар; музейлар эшләре, сәнгать бүлекләре; 1925 тән — туган якны өйрәнү бюросы); социаль һәм сәяси белем (секретариат; бердәм хезмәт мәктәбе, мәктәпкәчә тәрбия, 1922 дән — балигъ булмаганнарны социаль-хокукый яклау бүлекләре), 1920–21 елларда — халык мәгарифе бүлекләре, һөнәри-техник белем бирү (адм.-оештыру, югары уку йортлары, мәгариф, техник белем бирү, а.х. һәм урман хуҗалыгы буенча белем бирү хезмәткәрләрен әзерләү, су транспорты эшчеләре әзерләү, юл транспорты эшчеләре әзерләү, эшчеләргә һөнәри белем бирү, укыту-контроль, укучыларга хезмәт күрсәтү, сәнгать белеме бирү бүлекләре), мәктәптән тыш сәяси белем бирү (адм.-оештыру, агитация, пропаганда, наданлыкны бетерү, хуҗалык эше бүлекләре), дәүләт нәшрияты идарәсе (адм.-хуҗалык, нәшрият эшләре, техник, тарату, милли азчылык бүлекләре) баш идарәләрен; 1930 елларда — мәктәпләр, урта мәктәпләр, башлангыч мәктәпләр, өлкәннәр өчен мәктәпләр, сәяси-агарту идарәләрен; гомуми, мәктәпкәчә яшьтәге балалар, ятимнәр йортлары, кадрлар, капиталь төзелеш, планлаштыру-финанс бүлекләрен, бухгалтерияне, стат. төркемен, шикаятьләр бюросын, консультация пунктын, методик кабинетны; 1940 елларда — эшләр башкару, мәктәпләр, сәяси-агарту эше һәм өлкәннәр өчен мәктәпләр идарәләрен; эшчеләр һәм авыл яшьләре мәктәпләре, ятимнәр йортлары, мәктәпкәчә тәрбия, планлаштыру-финанс, кадрлар, тәэминат, төзелеш бүлекләрен; бухгалтерияне; стат. төркемен үз эченә ала. Халык комис-ты карамагында район (1930 га кадәр кантон), шәһәр халык мәгарифе бүлекләре, башлангыч, урта, сәяси-агарту мәктәпләре, техникумнар, пед. уч-щеләре, балалар бакчалары һәм башка мәктәптән тыш оешмалар, методик кабинетлар, ятимнәр йортлары һәм интернатлар, китапханәләр, уку өйләре, мәдәният сарайлары һәм йортлары, музейлар, культура һәм ял парклары, фәнни-тикшеренү учреждениеләре, һәйкәлләрне саклау оешмалары, кадрлар әзерләү курслары, Татарстан укытучылар белемен күтәрү ин-ты була. ТАССР ҮБКна (1938 гә кадәр), ТАССР ХКСна һәм РСФСРның шундый ук Халык комис-тына буйсына.

ТАССР Мәгариф халык комис-ты ТАССР ЮС Президиумының 1946 ел 28 март Указы б-н — ТАССР Мәгариф министрлыгы, ТАССР ЮС Президиумының 1988 ел 8 август Указы б-н — ТАССР (1990 нан — ТССР, 1992 дән — ТР) Халык мәгарифе министрлыгы, ТР Дәүләт Советының 1995 ел 22 июнь карары б-н — ТР Мәгариф министрлыгы, ТР Дәүләт Советының 2004 ел 9 сентябрь карары б-н ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы итеп үзгәртелә. Мәктәпкәчә, башлангыч, тулы булмаган төп һәм урта (тулы) гомуми, һөнәри, өстәмә, ш.у. пед. урта, югары, һөнәри, югары уку йортын тәмамлаганнан соң белем алу өлкәләрендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итә; 2004 тән ш.у. дәүләт мәгариф учреждениеләрендәге фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлек б-н идарә итә. Министрлык составына 1940 еллар уртасы — 1950 елларда — гомуми, мәктәпләр, эшчеләр һәм авыл яшьләре мәктәпләре (1949 га кадәр), ятимнәр йортлары, мәктәпкәчә тәрбия, планлаштыру-финанс, кадрлар бүлекләре, бухгалтерия, төзелеш төркеме; 1960–1980 елларда — гомуми, мәктәпләр, интернат-мәктәпләр, мәктәпкәчә тәрбия, төзелеш, кадрлар бүлекләре, бухгалтерия; 1990 елларда — канцелярия, оештыру-укыту эшләре, тәрбия эшләре, программалар һәм уку ярдәмлекләре әзерләү һәм бастыру, укыту-производство, хезмәтне саклау һәм хезмәткә өйрәтү, һөнәри әзерлек, кадрлар, планлаштыру-икътисад һәм финанс, комплектлаштыру һәм матди-техник тәэминат, контроль-ревизия бүлекләре; мәктәпкәчә тәрбия, интернат мәктәпләр, стат., торак-көнкүреш, хезмәткә өйрәтү, кадрлар әзерләү секторлары; бухгалтерия, техник күзәтчелек һәм капиталь төзелеш төркеме; 2000 елларда — мәгариф б-н программалы-максатчан идарә (эшләр башкару идарәсе, урта белем бирү б-н программалы-максатчан идарә, милли мәгарифне үстерү һәм төбәкара хезмәттәшлек, оештыру-аналитика, техник-хуҗалык хезмәте күрсәтү бүлекләре; мәктәпкәчә белем бирү, махсус һәм мобилизация эшләре, хатлар секторлары; канцелярия); башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү (башлангыч һөнәри белем бирүне үстерү, урта һөнәри белем бирүне үстерү, фәнни тикшеренүләрне, табуларны координацияләү һәм югары белем бүлекләре) департаментлары; мәгълүмат сәясәте (белем бирүдә мәгълүмати технологияләрне, мәгълүмат куркынычсызлыгының автоматлаштырылган идарә системасын үстерү; уку-укыту учреждениеләрен лицензияләү, аттестацияләү һәм аккредитацияләү, бердәм дәүләт имтиханнары бирүне оештыру бүлекләре); тәрбия эшләре (пед. ярдәм һәм реабилитация, тәрбия эшләрен һәм балаларга өстәмә белем бирүне үстерү, уку-укыту процессын комплекслы тәэмин итү һәм респ-ка милке бүлекләре); дәүләт хезмәте һәм кадрлар (кадрлар сәясәте, мәгариф өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек, өстәмә һәм югары уку йортын тәмамлаганнан соң һөнәри белем бирүне үстерү бүлекләре; пед. кадрларны, пед. уку йортларын аттестацияләү секторлары); планлаштыру, бюджет түләеше, бухгалтерлык исәп-хисабы һәм финанс тәэминаты (бюджетны планлаштыру икътисады һәм хезмәткә түләү; стат. күзәтчелек һәм икътисади анализ, бюджет чыгымнарын оптимизацияләү һәм норматив — җан башыннан финанслауны үстерү, бухгалтерлык исәп-хисабы бүлекләре) идарәләре; мәгарифне үстерү стратегиясен эшләү һәм хокук бүлекләре керә. Министрлык системасына балалар бакчалары һәм башка мәктәпкәчә тәрбия оешмалары, башлангыч, төп, урта мәктәпләр, интернат-мәктәпләр, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле булган балалар сыйныфлары, ятимнәр йортлары, һөнәри лицей, көллият һәм уч-щеләр, пед. көллиятләр, уч-щеләр һәм техникумнар, өстәмә белем бирү учреждениеләре, югары уку йортлары һ.б. карый .ТР Президентына, ТР МКна (1991 гә кадәр — ТАССР МС) буйсына.

Халык комиссарлары һәм министрлар: Х.Ш.Солтанов (1920–21), Ш.Г.Әхмәдиев (1921–22, 1924–26), М.Ю.Борындыков (1922–24), М.Х.Таһиров (1926–27), Н.К.Мөхетдинов (1927–28), И.Ш.Рәхмәтуллин (1928–31), А.Т.Биктаһиров (1932–34), Ш.Г.Башкиров (1934–37), Г.А.Бакиров (1937–38), З.Ф.Шәрипов (1938–39), У.Т.Контюков (1939–48), Г.Г.Әбүзәров (1948–50), Ә.Г.Вәлиуллина (1950–58), М.И.Мәхмүтов (1958–76), В.В.Иванов (1976–80), Р.А.Низамов (1980–90), В.Г.Гайфуллин (1990–97), Ф.Ф.Харисов (1987–2004), Р.Ф.Шәйхелисламов (2004–07), Н.М.Вәлиев (2007–2013), Э.Н.Фәттахов (2013 тән). Ш.у.к. *Культура революциясе*.

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ МИЛЛИ́ КИТАПХАНӘСЕ́**. 1865 елда шәһәр җәмәгать китапханәсе буларак оештырыла. Китапханә нигезен танылган библиофил И.А.*Второв* коллекциясе тәшкил итә, ул 903 исемдәге 1908 том китап һәм вакытлы матбугат басмасыннан тора (1844 тә И.А.Второвның улы, күренекле әдәбиятчы, археолог һәм этнограф Н.И.Второв әтисенең васыяте буенча аны шәһәргә бүләк итә). Китапханәнең абонементы һәм уку залы була. 1906 ның 2 гыйнварында Казанда мөселманнар өчен аерым ф-лы ачыла (шул чорда Россиянең татар мәгърифәтчелеге үзәкләренең берсенә әверелә). Филиалның башлангыч фонды үз эченә шәрекъ һәм рус телендәге басмаларны ала (төрле кешеләр тарафыннан бүләк ителгән 915 исемдәге 1277 том). Китап-басмалар табу авыр булуга карамастан, 1915 кә фондның рус телендәге тупланмасы — 767 исемдәге 1977 том һәм брошюрага, гарәп, татар телләрендәгесе 1496 исемдәге 1828 том китапка кадәр үсә.

1917 дә китапханә — Үзәк губерна китапханәсе, 1920 дән В.И.Ленин исемен ала. 1923 тә — Үзәк шәһәр китапханәсе. 1919 да китапханәнең мөселман ф-лы — 5 нче шәһәр китапханәсе, 1922 дә М.Вахитов исем. Үзәк шәрекъ китапханәсе итеп үзгәртелә. 1929 да аны Үзәк шәһәр китапханәсе б-н берләштерәләр. 1934 тә Үзәк китапханә — өлкә, 1941 дә

респ-ка китапханәсе итеп үзгәртелә (респ-када китапханә эше б-н методик җитәкчелек үзәге функцияләрен ала). 1965 тә, 100 еллык юбилее көннәрендә, китапханәгә фәнни китапханә статусы бирелә. 1991 нең 5 ноябрендә «Татарстан Республикасының Милли китапханәсенә В.И.Ленин исем. Республика фәнни китапханәсе статусы бирелү турында» ТР МК карары чыкканнан соң, китапханә милли мәдәният һәм милли мәдәниятләрнең үзара багланышлары үзәге буларак карала башлый. ТРның «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 1998 ел 28 ноябрь Законы нигезендә китапханәләрдә булган мәдәни кыйммәтләрдән файдалануга киң юл ачыла. Милли китапханә Татарстан халыкларының кыйммәтле мәдәни мирас объекты санала, аның фонды мемориаль әһәмияткә ия. Хәзерге вакытта фондларда 3,2 млн. данә документ исәпләнә (ш.и. 120 мең документ татар телендә, 81 меңе — чит телләрдә).

Китапханә структурасын 20 дән артык бүлек: хезмәт күрсәтү, мәгълүмат-библиография, документлар туплау, китап саклау, документларны фәнни эшкәртү һәм каталоглар, китапханәара абонемент һәм документларны электрон чаралар аша тапшыру, патент, татар һәм төбәкне өйрәнү әдәбияты, сәнгать, кульъязмалар һәм сирәк китаплар, вакытлы матбугат, фәнни-методик, редакция-нәшрият, чит телләрдәге әдәбият, халыкара һәм төбәкара китап алмашу, маркетинг, күргәзмәләр һәм мәдәни программалар, теркәү һәм статистика, китап б-н таныштыру һәм тышкы элемтәләрне үстерү, гигиена һәм документларны реставрацияләү, хуҗалык, ш.у. респ-ка китапханәләренә документлар туплау бүлекчәсе һ.б. тәшкил итә. Штатта 238 хезмәткәр, ш.и. югары белемле 182 белгеч бар. Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге фондында — татар, гарәп, төрек, фарсы, рус һ.б. телләрдә 60 меңгә якын берәмлек китап, 3 меңнән артык кульъязма һәм фотоматериал; рев-циягә кадәрге татар вакытлы матбугаты тупланмасы; тарих һәм мәдәният буенча төпле тикшеренүләр турындагы документлар; белешмә әдәбият, миниатюр басмалар тупланган. Монда Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре кульъязма күчермәләре, кульъязма Коръән (1699), 14 йөзгә караган фәлсәфи-этик әсәрләр тупланмасы, татар әдәбияты һәм мәгърифәтенең күренекле шәхесләре К.Насыйри, Ш.Мәрҗани, Г.Тукай һ.б.ның үзләре исән чактагы басмалары саклана. Китапханә Татарстан Респ-касы турындагы әдәбиятны һәм татар китапларын туплау, саклау һәм тарату вазифаларын башкаручы дөньядагы бердәнбер җәмәгать китапханәсе булып тора.

1993 тән китапханәдә компьютер мәгълүмати технологияләрен үзләштерү буенча эш башлана, 2000 дә китапханәнең http: // kitaphane.tatarstan.ru адреслы Web-сайты оеша, сайтта яңалыклар, китапханә тарихы, беренче китапханә, китапханә структурасы, мәгълүмати ресурслар, электрон китапханә, күрсәтелүче хезмәтләр исемлеге, документларны электрон чаралар аша тапшыру, халыкара китап алмашы, нәшрият эшчәнлеге, китапханә дуслары кебек төп мәгълүмат урнаштырыла. Веб-сайтта урнашкан электрон китапханә составында «Меңьеллык Казан», «Татар электрон китапханәсе», «Татарстан Республикасының күренекле мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре: белешмәлекләр», «Библиографик басмалар», «Яңа басмалар», «Сценарийларның тулы тексты» һ.б. барлыкка килә. 1999 да мәгълүмат-библиография бүлеге җирлегендә РФ Президенты каршындагы хөкүмәт элемтәсе федераль агентлыгы б-н килешү нигезендә Респ-ка хокукый мәгълүмат үзәге, мәдәният һәм сәнгать мәгълүмат үзәге (министрлыклар, мәдәни-агарту һәм уку-укыту оешмалары вәкилләренә индивидуаль рәвештә мәгълүмат бирү, белешмә кәгазьләре тутыру һ.б.ны гамәлгә ашыра) оеша. 2000 дә патент бүлегендә электрон уку залы ачыла, документларны электрон чаралар аша тапшыру хезмәте эшли башлый. Укучыларга телекоммуникацион элемтә каналлары аша еракта урнашкан башка китапханәләр: Россия дәүләт китапханәсе, Россия милли китапханәсе, Дәүләт тарихи җәмәгать китапханәсе, Иҗтимагый фәннәр фәнни мәгълүмат ин-ты һ.б. фондларында саклана торган документларны алу мөмкинлеге бирелә. 2000–01 елларда чит телләрдәге әдәбият бүлегендә мультимедиа мәгълүмат үзәге; АКШның Россиядәге илчелеге башлангычы б-н оешкан Америка үзәге; Гёте исем. немец мәдәни үзәге б-н хезмәттәшлек кысаларында оешкан махсус немец уку залы ачыла.

Милли китапханә тарафыннан «РУСЛАН» автоматлаштырылган китапханә-мәгълүмат системасы үзләштерелә; ул Татарстан Респ-касы китапханәләренең 600 меңнән артык библиографик язмасын куллану мөмкинлеге бирә торган «Татарстан Республикасы милли электрон китапханәсе» дәүләт мәгълүмат системасында катнашу б-н бергә аның операторы да булып китә. Китапханә һәм мәгълүмати технологияләр бүлеге китапханә фондларындагы документларны электрон вариантка күчерә һәм аларны, читтән торып кулланучыларны тәэмин итү өчен, Татарстан Респ-касының милли электрон китапханәсе порталына (http: // kitap.tatar.ru) урнаштыра.


1997 дә китапханәне гыйльми үзәк буларак үстерүгә булышлык итүче гыйльми совет барлыкка килә. Аның составына Казан ун-ты Фәнни китапханәсе, ТР Китап палатасы, Казанның югары уку йортлары: Казан ун-ты, Мәдәният һәм сәнгать академиясе вәкилләре, ш.у. ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының әйдәп баручы белгечләре керә. 2000 дә ТР МКның 2000 ел 6 апрель карары нигезендә Милли китапханә каршында Попечительләр советы оеша.

Милли китапханә респ-ка терр-ясендә урнашкан барлык төр китапханәләр эшчәнлеген фәнни һәм методик яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра. 2000 нән башлап ул ТР Мәдәният министрлыгының китапханә хезмәткәрләре арасында иҗади һәм инновацион активлыкны, һөнәри эшчәнлектә үсешне стимуллаштыруга юнәлтелгән бүләкләр тапшыру максатыннан уздырылучы «Лидер», «Иҗади эзләнүләр» конкурсларын да оештыра. Фәнни-методик бүлек респ-ка китапханәләренә ярдәмгә фәнни-методик материаллар әзерли. Наширлек эшчәнлеге Фәнни китапханә тарафыннан оештырыла, фәнни, белешмә, фәнни-популяр һәм фәнни-методик басмалар чыгаручы «Милли китап» нәшрияты тормышка ашыра. 1996 дан китапханәләрнең проф. тормышын яктыртучы фәнни-гамәли «Библиотечный вестник» ж-лы чыга.

Татарстанның Милли китапханәсе — Халыкара китапханәләр ассоциациясе әгъзасы, Россия китапханәләр ассоциациясе әгъзасы. Китапханәнең халыкара һәм төбәкара китап алмашу бүлеге якын һәм ерак чит илләр китапханәләре б-н хезмәттәшлек итә, аның абонентлары арасында эре чит ил китапханәләре: Төркия, Кытай, Франция, Германиянең милли китапханәләре, АКШ Конгрессы китапханәсе, Нью-Йорк җәмәгать китапханәсе, АКШ татарлары ассоциациясе китапханәсе һ.б. бар. Россиянең татарлар тупланып яшәгән төбәкләре (Төмән, Чиләбе, Пермь, Волгоград өлкәсе, Башкортстан, Мордва Респ-касы, Мари Респ-касы, Чуаш Респ-касы һ.б.) китапханәләре б-н милли һәм төбәкне өйрәнү әдәбиятын туплау өлкәсендәге хезмәттәшлек турындагы килешүләр төзелә. Чит ил һәм Россия китапханәләре б-н элемтәләрне киңәйтү уртак проектлар эшләү, тәҗрибә уртаклашу, белгечләр әзерләү, күргәзмә эшен оештыру һ.б. максатларны күздә тота.

*Р.У.Елизарова.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ МИЛЛИ́ МУЗЕЕ́**, фәнни-тикшеренү һәм мәдәни-агарту учреждениесе; ТР музейлары өчен музей белеме һәм методика үзәге. Баш музейны һәм ф-лларны эченә ала. 1894 елда Казан шәһәр фәнни-сәнәгать музее буларак нигез салына, 1895 нең 5 апрелендә тамашачылар өчен ачыла. Музей А.Ф.*Лихачёвның* шәхси коллекциясе һәм 1890 да Казанда үткәрелгән фән-сәнәгать күргәзмәсе экспонатлары нигезендә оеша. Музей коллекцияләрен оештыру һәм формалаштыруны Казан ун-тының күренекле галимнәре Н.Ф.*Высоцкий*, Н.П.*Загоскин*, Н.Ф.*Катанов*, П.И.*Кротов*, А.А.*Штукенберг* башлап җибәрә. Музей фондларын актив рәвештә коллекционерлар һәм меценатлар И.Ф.*Лихачёв*, А.Ф.*Лихачёв*, В.И.*Заусайлов*, О.С.*Александрова-Гейнс*, Г.*Баруди*, Д.И.Образцов һ.б. тулыландыра. Музейның уставы 1894 нең 17 мартында раслана. Аның нигезендә 5 бүлек: Лихачёв бүлеге, табигыять-тарих, тарих-этнография, уку-укыту, сәнәгать бүлекләре, ш.у. Музей советы оештырыла (1917 гә кадәр эшли). Музейның һәм һәрбер бүлекнең директорлары галимнәрдән билгеләнә (шәһәр думасы тарафыннан раслана). 1895 нең 5 апреленнән Казан шәһәр фәнни-сәнәгать музее шәһәрнең җирле үзидарә органнары карамагында була. Музей советының беренче рәисе итеп С.В.*Дьяченко* куела. Лихачёв бүлеге каршында шәһәр башлыклары җитәкләгән попечительләр советы эшли (1917 гә кадәр). 1918 дә — Губерна музее (Казан губерна башкарма ком-ты халык мәгарифе бүлегенең музейлар эше һәм сән-



ТРның Милли музее.

гать истәлекләрен һәм борынгы ядкәрләрне саклау бүлекчәсенә буйсына), 1921 дә — ТАССР Үзәк музее (башта *Академүзәкнең* музейлар бүлеге, 1930 дан ТАССР Мәгариф халык комис-ты карамагында), 1944 тә — ТАССР Дәүләт музее (1946 да ТАССР МС каршындагы мәдәният-агарту учреждениеләре эшләре идарәсенә, 1953 тән ТАССР Мәдәният министрлыгына буйсына). 2001 дән хәзерге исемдә. 1920 еллар уртасына музейда тарих-археол., этнография, шәрекъ кульязмалары, табигыять-тарих, тарих-көнкүреш, сәнгать, борынгы рус сәнгате бүлекләре ачыла. 1930 елларда төбәкне өйрәнү эзәрлекләнә, шуңа бәйле рәвештә музейның фәнни эшчәнлеге чикләнә. 1930 еллар ахырында музейда табигать, рев-циягә кадәр төбәк тарихы, совет җәмгыяте тарихы, массакүләм эшләр бүлекләре эшли.

1920 елларда ук Татарстан Дәүләт музее башка төбәкләр өчен координацияләүче методик үзәк ролен үти. 1981 дә респ-каның күпчелек музейларын үзәкләштерү нәтиҗәсендә ТАССР Берләштерелгән дәүләт музее оештырыла. Башта аңа 17 музей керә, яңа музейлар 1980–90 елларда ачыла. 2006 да берләштерелгән музей составына 75 музей-филиал керә. 2007 дән музейларның күпчелеге мөстәкыйльлек ала. Милли музей структурасында — 12 Казан музее: *Горький А.М. әдәби-мемориаль музее*, Шәриф Камал музей-фатиры да (к. *Камал Шәриф музей-фатиры*) булган татар әдәбияты тарихы музее, *Боратынский Е.А. әдәби музее, Җәлил Муса музей-фатиры, Тукай Габдулла әдәби музее, Сәйдәшев Салих музее, Җиһанов Нәҗип музей-фатиры, Насыйри Каюм музее*, Л.Н.Толстой музее, В.И.Ленин музей-йорты, 1941–45 еллардагы Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы, Татарстан Респ-касының муз. культура музее, ш.у. Югары Ослан районының Печищи авылында *Купала Янка музей-фатиры*, Кама Тамагы районының Красновидово авылында *Горький А.М. музее*. Баш музей элеккеге *Гостиный двор* бинасында урнашкан, 1995 тә, музейның 100 еллыгына, аның фасады реконструкцияләнә (арх. С.А.Козлова проекты); музей фондларында 910 меңнән артык саклау берәмлеге исәпләнә: Идел һәм Урал буе халыклары, ш.и. төрки һ.б. борынгы цивилизацияләр тарихы һәм мәдәниятенә, Көнбатыш һәм Көнчыгыш дөнья мәдәниятләренә карый.

Окт. рев-циясеннән соң сәнгать һәм борынгы ядкәрләрне исәпкә алу һәм саклау турында СССР ХКС декреты нигезендә музейда Казан ун-ты каршындагы Археол., тарих һәм этнография җәмгыятенең, элеккеге Вак һөнәрчелек земство музееның Бөтенроссия музей эшләре һәм сәнгать, борынгы ядкәрләрне саклау коллегиясеннән Пролетар рев-ция һәм шәрекъ халыклары музейларының конфискацияләнгән шәхси җыелмалары һәм коллекцияләре тупланган. 1921–22 дә музейга тарихи-сәнгати әһәмияте булган чиркәү әйберләре, Мәскәү дәүләт фондыннан 33 нәкышь сәнгате һәм скульптура әсәрләре кайта. Археол. фонды музей җыелмасының өчтән бер өлешен (246257 саклау берәмлеге) тәшкил итә. А.Ф.Лихачёвның Болгар коллекциясе (3080 берәмлек), Алтын Урда шәһәр-авыллары, Ананьино каберлекләре казылмалары материаллары (800 берәмлек), Яңа Мордва каберлеге стелалары (3) музейның горурлыгы булып тора. Уникаль Мисыр (250 берәмлек) һәм антик (420 берәмлек) коллекцияләр, алар арасында Мисыр хатын-кызы Ни-си-та-Уджат-ахетның таш табуты (саркофаг), фиргавен хәзинәләре сакчысының цилиндр сыман мөһере, б.э.к. 4 йөздә Апулиядә эшләнгән сирәк очрый торган кызыл фигуралы кратер. Нумизматика коллекцияләрен (120 меңнән артык саклау берәмлеге) антик, Европа, рус, шәрекъ, Алтын Урда акчалары, медальләр һәм күкрәк билгеләре тәшкил итә. Уникаль алтын акчалар җыелмасы (401 берәмлек): Александр Македонский заманындагы статерлар, Византия солидлары һ.б. 13–14 йөз Җучи акчалары хәзинәләре гаять зур фәнни әһәмияткә ия. Фондта 16–20 йөзләр язма чыганакларының 130 меңнән артык саклау берәмлеге: фән һәм мәдәният эшлеклеләренең архивлары һәм коллекцияләре, Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнашучыларның материаллары, документлар. Алар арасында — Сәхибгәрәй хан ярлыгы (1523), 17 йөз кульязма төргәкләре, В.М.*Флоринский*, Д.А.*Корсаков*, Ф.М.*Флавицкий*, П.М.*Дульский*, С.*Сүнчәләй*, Җ.*Фәйзи*, Ф.*Яруллин*, И.*Шәмсетдинов*, Г.*Камал*, Х.*Әбҗәлилов*, Г.*Болгарская*, А.*Ключарёв*, С.*Сәйдәшев*, Р.*Яхин* һ.б.ның автографлары һәм архивлары. Сирәк китаплар фондының төп өлешен (22 мең саклау берәмлеге) рус, татар һәм Көнбатыш Европа телләрендә язылган 17–20 йөзләр Россия, җирле һәм чит ил басмалары тәшкил итә. Уникаль кульязма һәм иске басма китаплар арасында (15–20 йөзләргә караган 233 басма, 88 кульязма китап) — 15 йөз Тверь Евангелиесе, 16 йөз «Казан елъязмачысы», 17–19 йөз Синодиклары, 16 йөз уртасы Иерусалим уставы һ.б. Татар халкы тарихы һәм мәдәнияте чыганаклары фондының нигезендә – татар мәдәнияте эшлеклеләренең шәхси әйберләре һәм китаплары. Алар арасында – Ш.*Мәрҗани*, К.*Насыйри*, Г.*Тукай*, *Дәрдемәнд*, Р.*Фәхретдин*, Г.*Исхакый*, Х.*Ямашев*, М.*Җәлил* һ.б.ның мемориаль әйберләре коллекцияләре, татар халкының рухи мәдәниятеннән материаллар. Кульязма һәм иске басма татар китаплары, Госман Коръәненең факсимиль басмасы, *шәмаилләр* җыелмасы, ш.у. урта гасырлар язуы истәлеге — Сарай шагыйре бакырчы оста Насыйрның Казан ханы Мөхәммәдәминдә хезмәт итүче гаскәр башлыгы Күбеккә бүләк ителгән 16 йөз кувшинындагы шигыре аеруча зур кызыксыну уята.

Этнография коллекциясе (25 меңнән артык саклау берәмлеге) Урта Идел буе халыклары: татарлар, руслар, марилар, удмуртлар, мордвалар, чуашлар, башкортларның көнкүреш предметларын, киемнәрен, бизәнү әйберләрен эченә ала. Казан татарларының кабатланмас гамәли-бизәлеш сәнгате коллекцияләре (3,5 мең саклау берәмлеге) – алтын җепләр б-н чигү, мозаикалы күн аяк киеме, зәркән бизәнү әйберләре, тукымалар, чигелгән традицион интерьер предметлары, шәмаилләр. Күрсәтмә материаллар фондында (73877 саклау берәмлеге) 20 йөзгә караган негатив, гравюра, фотография, открытка, плакат коллекцияләре бар. Җирле осталарның рәсемнәре, графика һәм скульптура, ш.и. Б.*Урманче* әсәрләре саклана. Әйберләр фонды (12,2 мең саклау берәмлеге) 18 йөз каретасын, «Фордзон-Путиловец» тракторын, ПО-2 самолётын, ГАЗ-А автомобилен, Россиядә, Көнчыгышта, Көнбатыш Европа илләрендә җитештерелгән фарфор һәм керәч кол-







ТРның Милли музее. 1. Казан татарларының зәркән бизәнү әйберләре; 2. «Татарстанның борынгы тарихы» экспозициясе фрагменты; 3. Карета. 18 йөз.

лекцияләрен (2,5 мең саклау берәмлеге) эченә ала. Кораллар фондына (915 саклау берәмлеге) — төрле илләрнең салкын һәм ату кораллары, ш.и. 10–11 йөзләрдәге 2 каролинг кылычы, 16 йөз затинная пищале, фитәле, тәгәрмәчле, бәрмә-чакма йозаклы кораллар. Табигый фондны — музей тупланмалары арасында иң борынгысы — геол.-минералогия, палеонтология, ботаника, зоология коллекцияләре тәшкил итә. 19 йөз ахырында Британия Табигыять тарихы музееннан алынган колибри коллекцияләре (36 берәмлек), чыпчыклар семьялыгыннан Америка кошлары (41 берәмлек); Император сарае министрлыгы бүләкләре (1902), алар арасында гигант кырпы балыгы, зубр сөкәтләре фәнни яктан аеруча кызыклы. Табигый коллекцияләрнең алтын фондында — исемнәре Европа һәм Россиянең зур музейларында 19–20 йөзләрнең танылган әйдәп баручы таксидермистлары Ф.Ф.Шиллингер, Э.Д.Пельцам, Я.П.Коксин эшләре.

1987 нең декабренә кадәр музейда ел саен яңа күргәзмәләр ачыла һәм элеккеләре эшли. 5 мең $м^2$ лы экспозиция төбәкнең табигый үзенчәлекләрен, аның үткәнен һәм хәзергесен чагылдыра. 1987 дә музей бинасына янгыннан зыян килә, даими экспозицияләр җыеп алына. 2004 тән, Кремль урамындагы бина яңадан торгызылганнан соң, «Татарстанның борынгы тарихы», «18 йөздә Казан губернасы» һ.б. даими экспозиция бүлекләре ачыла башлый. Даими экспозициянең мәйданы — 2,5 мең $м^2$ га, күргәзмә заллары — 1 мең $м^2$ га якын. Музейда төрле тематик күргәзмәләр уздырыла. Җәмәгатьчелеккә түбәндәге күргәзмәләр тәкъдим ителә: «Табигатькә тәрәзә» (1991 дән, Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы күрсәтелә); «Республиканың беренче әләме» (1998, 19 йөз ахырыннан 1920 елларга кадәр Татарстан тарихын чагылдыра); «Билгесез ил» (1997–2001, Болгар чорына кадәрге Идел-Кама буйларында яшәгән кабиләләр тарихы буенча археол. материаллар б-н таныштыра); «Г.Исхакыйның туган иленә кайтуы» (1998); «Ул синең белән безнең биография» (1999, комсомолның 80 еллык юбилеена); «Йөрәкләрнең яшерен кыллары» (1999–2000, дөнья халыкларының традицион, проф., мемориаль музыка уен кораллары күрсәтелгән); «Әфган реквиемы» (1998, 1999, 2000); «Уллар бурычы хакына» (1999–2000); «Без бар идек, без бар һәм булачакбыз» (1999–2000, С.Максудига багышлана); «Бөек Ватан сугышы елларында Казан» (2000); «Татарстан байлыклары: Берләштерелгән дәүләт музее ядкәрләре» (2000); «Казанча чәй эчү» (2001); «Гаҗәеп табигый фонд» (2003); «Мин үземә һәйкәл куйдым, гаҗәеп, мәңгелек...» (2003, Г.Р.Державин туууына 260 ел тулу уңаеннан); «Батыр үләр үлмәс дан алып» (2004, Муса Җәлил һәм җәлилчеләрнең һәлак булуына 60 ел тулуга карата); «Музей раритетлары — Казанның меңьеллыгына» (2005); «Театр тылсымы» (2006); «Билгесез бөек сугыш. 1914–1918» (2014); «Уңган халкымның оста куллары: татар халык һөнәрләре» (2016) һ.б. Музей төбәкнең әйдәп баручы фәнни-тикшеренү һәм мәгариф үзәкләреннән берсе, Татарстан ха-



ТРның Милли музее.
Зәркән бизәнү әйберләре өчен шкатулка. 19 йөз.

лыкларының тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертә. Музей ирешкән уңышлар, башлыча, П.М.Дульский, П.Е.*Корнилов*, Н.Ф.*Калинин*, М.Г.*Худяков*, Г.С.*Гобәйдуллин*, Е.П.*Бусыгин*, Е.Г.*Бушканец*, Г.Н.*Вульфсон*, М.К.*Мөхәррәмов*, И.Р.*Таһиров*, А.Х.*Халиков*, Р.И.*Нәфыйгов*, Б.Ф.*Солтанбәков*, А.Л.*Литвин*, М.Г.*Госманов* кебек галимнәрнең эшчәнлеге б-н бәйле.

1920 елларда татар халкының мәдәниятен һәм көнкүрешен өйрәнү һәм музей фондларын тулыландыру максаты б-н респ-ка районнарына беренче этнографик экспедицияләр оештырыла. 1938 дә СССР ФАнең Матди культура ин-ты, Дәүләт Тарих музее, ТАССР Үзәк музее планлы рәвештә бергәләшеп Идел буе Болгар дәүләтенең башкаласын өйрәнә башлыйлар.

1895–1917 дә — Казан шәһәр фәнни-сәнәгать музееның еллык басмасы, 1921–24 тә «*Казанский музейный вестник*» ж-лы нәшер ителә; 1995 тә еллык басмалар яңадан басыла башлый.

ТРның милли музее — респ-каның музей эшләрендә мәгълүмат технологияләре лидеры. 2002 дән музейда КАМИС-2000 системасы эшләп килә. Музей респ-ка музейларында КАМИС системасын кертүче методик үзәк булып тора. Музейның мәдәни-мәгариф эшчәнлеге төрле социаль катламдагы һәм төрле яшьтәге тамашачыларга юнәлдерелгән. Милли музей һәм аның ф-ллары каршында Алтын җепләр б-н чигү остаханәсе, Казанның борынгы ядкәрләрен сөючеләр түгәрәге, «Замандаш», «Борынгы ядкәрләрне саклаучы» клублары, Әдәби салон һәм муз. кунакханә, К.Насыйри музее каршында «Сәламәт яшәү рәвеше» клубы, А.М.Горький мемориаль музее каршында «ЛиМук» һәм «КЛИ» клубы, М.Җәлил музей-фатиры каршында «Кызыл ромашка» клубы һ.б. эшли.

Музей директорлары: С.В.Дьяченко (1895–1901), А.А.Штукенберг (1901–05), Н.П.Загоскин (1905), П.И.*Кротов* (1905–06), Н.Ф.Катанов (1906–12, 1914–17), М.Д.*Рузский* (1912), Г.П.*Кириллов* (1913), Б.Ф.*Адлер* (1918–22), Н.И.*Воробьёв* (1922–30), М.И.Борисов (1930–33), Е.И.*Медведев* (1933–34), Л.А.Әхмәтшин (1934–35), Г.Н.Республиканец (1935–37), Г.Б.Вахламов (1937–41), В.М.*Дьяконов* (1941–77), Л.Г.Вәлиева (1978–87), Г.С.*Муханов* (1987–2006), Г.Р.Нәҗипова (2006 дан).

М у з е й б а с м а л а р ы: Издания музея. 1894–1956 / Төз. Г.А.Скопин. К., 1957; Каталог знамён в фондах музея. К., 1958; Каталог материалов музея по периоду подготовки и проведения Великой Октябрьской социалистической революции и Гражданской войны: В 3 вып. К., 1958–59; Муса Джалиль (Залилов): Каталог материалов в фондах музея. К., 1959; Автографы в собрании музея: Каталог. К., 1960; Каталог скульптуры. К., 1961; Каталог археологических коллекций: В 2 вып. К., 1975–80; Из коллекции Государственного объединённого музея Республики Татарстан. К., 1994; З а в ь я л о в а М.К. Татарский костюм: Из собрания Государственного музея Республики Татарстан. К., 1996; Г а с и м о в О.Р. Оружие в собрании Национального музея Республики Татарстан. К., 2003; Я к о в л е в В.И. Музыкальные инструменты Национального музея Республики Татарстан: Каталог. К., 2007.

*Әд.:* Казанский губернский музей за 25 лет: Юбилейный сб. статей. К., 1923; Д ь я к о н о в В.М. Жизнь и музей. М., 1963; М у х а н о в Г.С. История Государственного музея Республики Татарстан в зеркале XX века. К., 1997; Назипова Г.Р.Казанский городской музей: Очерки истории 1895–1917 годов. К., 2000; Наследие веков: Из собраний Государственного музея Республики Татарстан: Альбом. К., 2000.

*Г.С.Муханов, Г.Р.Нәҗипова.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ МУСА́ ҖӘЛИ́Л ИСЕМЕНДӘГЕ́ РЕСПУ́БЛИКА БҮЛӘГЕ́**. 1968 елда ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты карары нигезендә Муса Җәлил исем. Татарстан комсомолы бүләге буларак гамәлгә кертелә. 1990–97 дә бирелми, 1997 дән хәзерге исемдә. Яшь авторларның: язучылар, журналистлар, композиторлар, рәссамнарның иң яхшы әсәрләре, башкару сәнгате, кинематография һәм журналистика өлкәсендәге, 1976 дан — ш.у. фәнни-җитештерү һәм пед. өлкәсендәге, 1997 дән — яшьләр эшмәкәрлеге, яшьләр программаларын тормышка ашыру өлкәсендәге казанышлар өчен ике елга бер тапкыр 4 бүләк (аерым кешеләргә һәм коллективларга) бирелә.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ НӘШРИЯ́Т, ПОЛИГРА́ФИЯ ҺӘМ КИТА́П СӘҮДӘСЕ́ ЭШЛӘРЕ́ ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**, к. *Татарстан Республикасы Матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ РӘССАМНА́Р БЕРЛЕГЕ́**, рәссамнарны һәм сәнгать белгечләрен берләштерүче иҗат оешмасы. ТАССР ҮБКның «ТАССР совет рәссамнары җәмгыяте уставын раслау турында»гы һәм ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты бюросының 1935 елда кабул иткән карарлары нигезендә 1936 елның 8 декабрендә оештырыла. Булачак рәссамнар берлегенең үрнәге итеп *ТатАХРР* алына, берлек составына аның күп кенә актив эшлекләре керә. 1920 еллар ахыры — 1930 еллар башында респ-ка рәссамнарының хәле матди-җитештерү базасының зәгыйфьлеге, сәнгать әсәрләренә заказлар оештыру һәм аларны сату эшенең тәртипкә салынмавы, рәссамнар тормыш-көнкүрешен кайгыртмау б-н характерлана. Дәүләт, иҗат берлекләре оештырып, аларның эшчәнлеген күзәтү б-н бергә өлешчә финанс һәм социаль тәэмин итүне дә үз өстенә ала. Берлек әгъзалары өстәмә торак мәйданыннан, иҗат йортлары, иҗат остаханәләреннән һ.б.дан файдалану хокукына ия була. 1935 нең октябрендә ТАССР

ХКС тарафыннан соңрак иҗат берлеге эшчәнлеген тулы көченә җәелдерүгә матди база булган «Сәнгать-җитештерү остаханәләрен оештыру турында» карар кабул ителә (к. *Татарстан Республикасының Сәнгать фонды*).

1930 елларда ТАССР Рәссамнар берлегенең формалашуы сәяси репрессияләр фонында бара: аның күп кенә әгъзалары кулга алына. Бөек Ватан сугышы башлангач, рәссамнарның күбесе фронтка китә, 14 кеше һәлак була (П.М.Байбарышев, Н.К.Вәлиуллин, Г.Я.Мусин, А.Г.Силантьев, Г.Е.Соколов һ.б.). ТАССР шәһәрләренә совет әдәбияты һәм сәнгате эшлеклеләре эвакуацияләнә, 1941 дә берлеккә 24 рәссам беркетелә.

ТР Рәссамнар берлеге мөстәкыйль оешма буларак формалаша (1935–36 да әле СССР һәм РСФСР Рәссамнар берлекләре булмый). 1939 ның июнендә СССР ХКС җирле оешмалар эшчәнлеген күзәтергә тиешле Совет рәссамнары берлеген төзү турында карар кабул итә (оештыру ком-ты президиумы ТАССР Рәссамнар берлеге әгъзасы булган 47 кешенең бары 28 ен генә раслый; 1953 нең гыйнварына аның составына 37 кеше керә). 1957 дә, СССР Рәссамнар берлегенең оештыру съездыннан соң, ТАССР Рәссамнар берлеге СССР Рәссамнар берлегенең Татарстан бүлеге итеп үзгәртелә (1960 ка кадәр). 1960–68 дә РСФСР Рәссамнар берлегенең Татарстан бүлеге буларак яши. 1968 нең ноябрендә рәссамнарның 3 нче Бөтенсоюз съездында СССР Рәссамнар берлеге Уставына автономияле респ-каларның иҗади хокукларын киңәйтү б-н бәйле үзгәрешләр кертелә. РСФСР Рәссамнар берлегенең Татарстан бүлеге ТАССР Рәссамнар берлеге итеп үзгәртелә. 1971 нең октябрендә Казанда ТАССР Рәссамнар берлегенең 1 нче съезды ачыла; бу вакытта Берлек составында 50 кеше исәпләнә; 1975 нең сентябрендә ТАССР Рәссамнар берлегенең 2 нче съезды ачылышына Рәссамнар берлеге 59 кешегә җитә. 1980 дә Казанда «Зур Идел» зона күргәзмәсе шул уңайдан төзелгән Күргәзмәләр залы бинасында ачыла. Ләкин 1990–2000 елларда Россия җәмгыятендәге соц.-икътисади үзгәрешләр рәссамнарның хәлен авырайта. Алар дәүләт заказларыннан, күргәзмәләр залы биналарыннан һәм Сәнгать фондыннан мәхрүм ителә. З.Ф.Гыймаев җитәкчелегендәге идарә тырышлыгы нәтиҗәсендә, ТР Рәссамнар берлеге иҗат оешмасы буларак сакланып кала. Берлек әгъзалары респ-ка сәнгате тормышында һәм аның чикләрендәге халыкара, бөтенроссия һәм зона күргәзмәләрендә актив катнашалар. Аларның күпчелеге респ-каның дәүләт бүләге, хөкүмәт бүләкләре, мактаулы исемнәр б-н билгеләп үтелә. 2016 да ТР Рәссамнар берлеге составында 311 кеше исәпләнә.

Рәссамнар берлеге җитәкчеләре: П.М.*Дульский* (1936–38), В.К.*Тимофеев* (1938–39), Н.К.*Вәлиуллин* (1939–40), К.С.Счастнев (1940–41), С.С.*Ахун* (1941–51), Х.Г.*Якупов* (1951–75), Ә.И.*Тумашев* (1975–86), В.М.*Маликов* (1986–88), Ә.Н.*Мәҗитов* (1988–91), Н.У.*Әлмиев* (1991–93), А.Ә.Абызгилдин (1993–2008), З.Ф.Гыймаев (2008 дән).

*М.Е.Ильина.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ РЕАБИЛИТА́ЦИЯ ҮЗӘКЛӘРЕ́**, ТРның социаль яклау системасы карамагындагы, эшчәнлеге инвалидларны реабилитацияләүгә, организмның функцияләрен тергезүгә юнәлдерелгән мед. учреждениеләре. Казанда эшләүче үзәкләр: Респ-ка реабилитация-техник үзәге (реабилитация чаралары б-н тәэмин итә, алардан файдалану ысулларына өйрәтә), социаль-конкүреш адаптациясе һәм дистанцион өйрәнү бүлекләрен, реабилитация чараларын эшләү һәм төзәтү цехларын эченә ала; балалар һәм яшүсмерләрне мед. һәм социаль яктан реабилитацияләү б-н шөгыльләнүче 4 үзәк; Левченко посёлогындагы махсус мед. укыту-тәрбия мәктәбе. Мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен шәһәр һәм шәһәр тибындагы посёлокларда: Яшел Үзәндә («Идел», «Доверие»), Түбән Камада («Надежда»), Баулыда («Радость»), Бөгелмәдә («Возрождение»), Чаллыда («Солнышко»), Минзәләдә («Умырзая»), Лениногорскида («Алый парус»), Кукмарада («Милосердие»), ш.у. Лаешта һәм Арчада үзәкләр төзелә. Хезмәт яшендәге инвалидлар өчен Казанда («Восхождение», «Крутушка»), Чаллыда («Изгелек»), Әлмәттә («Ветеран»), Баулыда («Берёзка), Азнакайда («Ак чишмә») Яшел Үзәндә («Идел), Арчада («Надежда») үзәкләр эшли. Инвалидларны реабилитацияләүдә иппотерапия, кинезиотерапия, Монтессори коррекцион педагогикасы ысулы (балаларны укыту) һ.б. кулланыла, ишетү сәләте зәгыйфь балаларның сәламәтлеген тергезү Леонгард системасына нигезләнә. Әлеге үзәкләрдә амбулатор, стационар, консультатив тәртиптә эшләүче, балалар өчен уку-укыту эшчәнлеге алып барыла торган, интернат тибындагы үзәкләр булдырыла. 2011 дә ТРда балалар өчен — 15, өлкәннәр өчен 8 реабилитация үзәге исәпләнә, аларда 1100 кеше хезмәт куя. Ел саен 18 меңнән артык инвалид квалификацияле ярдәм ала. Реабилитация үзәкләре составына мед. һәм социаль-психол. хезмәтләр, агач һәм тегү эше остаханәләре керә, аларда педагоглар, тәрбиячеләр, хезмәткә өйрәтү остазлары эшли. Кайбер учреждениеләрдә спорт һәм тренажёр заллары бар; спорт секцияләре, сәнгать студияләре, үзешчән коллективлар оештырылган.

*А.Е.Кондаков, Р.Г.Исхакова.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ РСФСРдагы́ ВӘКАЛӘТЛЕ́ ВӘКИЛЛЕГЕ́**, ТАССР дәүләт хакимияте башкарма органы. 1920 елда Мәскәүдә гамәлдән чыгарылган *Эчке Россия мөселманнары эшләре комиссариаты* җирлегендә ачыла. Башта РСФСРның Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты каршында, 1924 нең апреленнән Бөтенроссия ҮБК Президиумы каршында эшли. ТАССРның сәяси, икътисади, милли һәм мәдәни мәнфәгатьләрен РСФСР югары дәүләт хакимияте органнарына җиткерә. 1938 нең декабрендә гамәлдән чыгарыла.

Төрле еллардагы җитәкчеләре: *А.Г.Ганиев, Г.М.Енбаев, С.М.Еникиев, И.К.Неометов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ САТЫ́П АЛУЛА́Р ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**. ТР МКның 2006 ел 15 сентябрь карары һәм ТР Президентының 2006 ел 23 октябрь Указы нигезендә ТРның дәүләт күләмендә сатып алулар идарәсе буларак оештырыла, ТР Президентының 2014 ел 20 март Указы һәм ТР Дәүләт Советының 2014 ел 20 март карары б-н хәзерге исемендә. Татарстан ихтыяҗлары өчен товар сатып алу, эшләр башкару, хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәрүне тормышка ашыра. Үз эченә эшләр башкару идарәсен; үзәкләштерелгән сатып алулар, бер үзәктән сатып алуларны анализлау һәм тәэмин итү, дәүләт контрактларын гамәлгә ашыру, сатып алулар методологиясен тәэмин итү, кадрлар, бухгалтерия бүлекләрен ала. ТРның Сатып алулар Дәүләт ком-ты системасына ТРның Сатып алуларны үстерү үзәге керә. ТР Президентына һәм ТР МКна буйсына.

Рәисе: О.А.Редько (2014 елдан).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ СӘНГА́ТЬ ФОНДЫ́**, рәссамнарның иҗат остаханәләре берләшмәсе, сәнгать-җитештерү пр-тиесе. 1935 елда ТАССР ХКС карары нигезендә төзелә. 1953 кә кадәр «Татхудожник» — рәссамнарның Бөтенсоюз кооперативы берлеге Татарстан бүлеге карамагында; 1953–79 да РСФСР Сәнгать фондының Татарстан бүлеге, 1979–95 тә РСФСР Сәнгать фондының Татарстан иҗади-җитештерү комб-ты, 1995 тән хәзерге исемдә. *Татарстан Республикасының Рәссамнар берлегенә* матди-җитештерү базасы булып хезмәт итә. Остаханәләре Казан, Чаллы, Түбән Кама, Бөгелмә, Лениногорск, Алабуга шәһәрләрендә эшли. Иҗади эшчәнлегенең төп төрләре: сәнгать-бизәлеш эшләре, станлы нәкышь һәм скульптура, монументаль бизәлеш һәм гамәли бизәлеш сәнгате, тиражлы графика, интерьерлар дизайны. 2008 дә ТР С.ф. үзенең эшчәнлеген туктата.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ СТАТИ́СТИКА ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**. РСФСР ХКСның 1918 ел 3 сентябрь карары нигезендә оештырыла һәм шул ук елның 19 октябрендә Казан губерна стат. бюросы буларак ачыла; БҮБК һәм РСФСР ХКСның 1920 ел 27 май Декреты һәм ТАССР ҮБКның 1920 ел 28 сентябрь карары б-н — ТАССР Стат. идарәсе, СССР ХКСның 1931 ел 9 май карары б-н Татарстан халык-хуҗалык исәбе идарәсе итеп үзгәртелә, СССР ХКСның 1941 ел 26 май карары б-н ТАССР Стат. идарәсе буларак кабат торгызыла, РСФСР Үзәк стат. идарәсенең 1987 ел 14 октябрь боерыгы б-н — Татарстан Респ-ка стат. идарәсе, ә РФ Дәүләт стат. ком-тының 1992 ел 14 май карары б-н ТР С.д.к. итеп үзгәртелә. Исәп-хисап һәм стат. эшләрен башкара. Мәгълүмат чыганагын пр-тие, оешма һәм учреждениеләрнең агымдагы һәм еллык хисаплары, ш.у. аерым башкарыла торган эре икътисади исәпләүләр һәм сан алулар тәшкил итә. Тәбәк статистикасы; милли хисап һәм түләү балансы; пр-тиеләр статистикасы; товар базарлары статистикасы; хезмәт статистикасы; конъюнктура статистикасы һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтү; статистиканы мәгълүматлаштыру; стат. органнарын һәм бухгалтерлык хезмәте идарәләрен

финанслау; агросәнәгать комплексы статистикасы; капиталь төзелеш статистикасы; транспорт һәм элемтә статистикасы; социаль стат. һәм халыкка хезмәт күрсәтү; фән һәм техника статистикасы; бәяләр статистикасы; халык бюджеты статистикасы; демографик стат.; икътисади анализ һәм автоматлаштырылган мәгълүмат базасы; классификаторлар һәм регистрлар алып бару; махсус мәгълүматны эшкәртү; стат. хисабы бланклары б-н тәэмин итү; ЭВМнар б-н эшләү; ЭВМнарга техник хезмәт күрсәтү; бердәм ЭВМ статистикасы мәгълүматларын әзерләү; кадрлар һәм хокук; матди-техник тәэминат һәм транспорт; нәшрият үзәге бүлекләрен үз эченә ала. Дәүләт ком-ты составына Казан шәһәр стат. ком-ты, район һәм шәһәр стат. идарәләре һәм бүлекләре керә. РФнең шул ук исемдәге Дәүләт ком-тына, ТР Президентына һәм ТР МКна (1991 гә кадәр — СССР Үзәк стат. идарәсенә) буйсына. РФ Дәүләт стат. ком-тының 2002 ел 20 декабрь боерыгы нигезендә ТРның Дәүләт статистикасы ком-ты итеп үзгәртелә.

Төп басмалары: «ТАССР Статистика идарәсе бюллетене» («Бюллетень Статистического управления ТАССР», № 1–9, 1920–22), «Икътисади бюллетень» («Экономический бюллетень», № 1–47, 1923), «Бәяләр статистикасы бюллетене» («Бюллетень статистики цен», 1924–28), «ТАССР буенча популяр белешмәлекләр сериясе» («Серия популярных справочников по ТАССР», вып. 1–3, 1924–25), «ТАССР Статистика идарәсе материаллары» («Материалы Статистического управления ТАССР», т. 1–3, 1928), «ТАССР халык хуҗалыгы (1957–91)» («Народное хозяйство Татарской АССР», 1957–91), «Татарстан Республикасы: Статистик җыентык (1998–2001)» («Республика Татарстан: Статистический сборник», 1998–2001).

Рәисләре: А.М.Габетдинова (1992–95), Р.Ә.Хөснетдинов (1995–2000), В.П.Кандилов (2000–2002).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ТАБИГАТЬНЕ́ САКЛА́У ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**, к. *Татарстан Республикасы Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛА́Р ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**. ТР Президентының 2008 ел 25 гыйнвар Указы б-н ТРның тарифлар ком-ты буларак оештырыла, ТР Президентының 2010 ел 22 апрель Указы һәм ТР Дәүләт Советының 2010 ел 22 апрель карары б-н — хәзерге исемендә. Татарстанда товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтү өлкәсендә тарифлар, бәяләр, өстәп түләү, өстәмә бәяләр һ.б.ны дәүләт күләмендә көйләүне гамәлгә ашыра. Үз эченә коммуналь өлкәдәге оешмалар эшчәнлеген көйләү идарәсен; катнаш җитештерүле җылылык энергиясе тарифларын көйләү, технол. ялганыш өчен түләүне көйләү һәм контрольдә тоту, электр энергиясе тарифларын көйләү, транспорт һәм элемтә хезмәте тарифларын көйләү, кулланучылар базарындагы бәяләрне көйләү һәм контрольдә тоту, тарифлар буенча карарлар кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм җыелма, мәгълүматлаштыру, техник аудит һәм инвестиция программалары, адм. эшчәнлек, гражданнар мөрәҗәгатьләре б-н эшләү, эшләр башкару, гомуми бүлекләрне ала. ТР Президентына һәм ТР МКна буйсына.

Рәисләре: М.А.Фәйрушина (2010–11), Р.М.Хаҗиев (2011–12), М.Р.Зарипов (2012 дән).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ТАРИХИ́-СӘЯСИ́ ДОКУМЕНТЛАРНЫ́ САКЛА́У ҮЗӘ́К ДӘҮЛӘ́Т АРХИВЫ́**. 1929 елның 18 маенда ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты секретариаты карары буенча ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты партия тарихы бүлеге каршында партия архивы буларак оештырыла; 1929 ның 28 июнендә ВКП(б)ның ҮК секретариаты тарафыннан расланган «ВКП(б)ның Бердәм партия архивы турында күрсәтмә»гә нигезләнеп, Бердәм партия архивы ф-лы буларак эшли. Партия архивы алдына җирле оешмалар тарихына караган документларны җыю, саклау һәм өйрәнү бурычлары куела. Аның нигезен Истпартның Казан бүлеге хезмәткәрләре М.К.Корбут, С.Лифшиц, Н.Знаменский һ.б. тарафыннан җыелган Казан губернасы сәяси партияләре һәм революцион хәрәкәтләре тарихына караган документлар тәшкил итә. 1939 ның 2 декабрендә Истпарт бүлекләре ябылганнан соң, партия архивы ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты карамагына күчә. 1953–59 да КПССның Татарстан өлкә ком-ты каршындагы Партия тарихы ин-тына буйсына. 1960 та КПССның Татарстан өлкә ком-ты партия архивы итеп үзгәртелә, 1990 ның сентябреннән — КПССның Татарстан респ-ка ком-тының партия архивы. РСФСР Президентының 1991 ел 6 ноябрь «РСФСР Коммунистлар партиясе һәм КПСС эшчәнлеге турында» Указына, ТССР МКның 1991 ел 10 ноябрь карарына нигезләнеп, партия архивы җирлегендә Татарстанның иң яңа тарихына кагылышлы документларны саклау һәм өйрәнү үзәге оештырыла, ул ТР МКның 1996 ел 7 март карары б-н ТР Т.-с.д.с.ү.д.а. итеп үзгәртелә. Архив документларны саклый һәм аларның исәбен алып бара, документларның халәтен яхшырту буенча эш башкара, «югалып баручы» текстларны торгыза, архив фондларын туплауны дәвам итә, до-



ТРның тарихи-сәяси документларны саклау үзәк дәүләт архивы бинасы. Казан.

кументларның фәнни һәм гамәли мөһимлегенә экспертиза үткәрә, аларның серлелеген гамәлдән чыгара. 2012 нең 1 гыйнварына архивта 1883–2011 гә караган 1038249 дан артык саклау берәмлеге булган 4914 фонд һәм 9878 фотодокумент исәпләнә. Фәнни-белешмә китапханәдә 4500 дән артык китап, рев-циягә кадәрге һәм совет хакимиятенең беренче елларындагы 1814 данә журнал, 1857–1998 дәге рус һәм татар телләрендәге газеталарның 656 тупламасы саклана. Архивның фәнни-белешмә аппараты тасвирламалардан, фондлар буенча һәм системалы каталоглардан, тематик һәм исемле белешмәлекләрдән, партия һәм комсомол органнарының конференцияләрендә, пленумнарында, активларында, бюро һәм секретариат утырышларында каралган мәсьәләләр исемлегеннән гыйбарәт. Фондларның документлары төп эш башкару кәгазьләренең һәм персональ характердагы эшләр тасвирламалары яки ике төр документларны да үз эченә алган тасвирламалар буенча урнаштырылган. 1991 гә кадәр архив партия һәм комсомолның өлкә, район, шәһәр һәм беренчел оешмалары документлары б-н туплана (алар архив фондларының төп өлешен тәшкил итәләр). Архивта КПСС һәм комсомол эшчәнлеге турындагы чыганаклардан тыш, ТАССР төзелү, респ-када сәнәгать үсеше турындагы мәгълүматлар, заводлар, колхозлар, совхозлар, уку йортлары һәм мәдәният оешмалары тарихы буенча документлар да саклана. Фондларда 1941–1945 елларда Бөек Ватан сугышында катнашучыларның хатлары, фоторәсемнәре, шәхси документлары; рев-ция вакыйгалары, Гражданнар сугышы, күмәкләштерү турындагы хатирәләр, мәкаләләр, шәхси документлар; партия һәм комсомол ветераннарының, революцион хәрәкәтләрдә, Гражданнар сугышында һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның фоторәсемнәре, хатлары бар. 1993 тән архив саклау өчен иҗтимагый-сәяси оешмаларның, партияләрнең һәм хәрәкәтләрнең документларын кабул итә (фондларда Бөтентатар иҗтимагый үзәге, «Ватан» оешмасы, «Бердәмлек һәм прогресс» партиясе, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-ты һ.б.ның эшчәнлеге турындагы материаллар саклана). РСФСР Президентының «СССР дәүләт куркынычсызлыгы комитеты архивлары турында» 1991 ел 27 август Указы нигезендә 1993–95 тә ТР Дәүләт куркынычсызлыгы ком-ты тарафыннан Татарстанда туган элеккеге хәрби әсирләрнең сер булудан туктаган документлары һәм 1920–50 елларда репрессияләнгән фән, әдәбият, сәнгать эшлеклеләренең (алар арасында Һ.Атласи, Г.Ибраһимов, К.Нәҗми, Б.Урманче документлары бар) архив-тикшерү эшләре саклау өчен тапшырыла. 1924–97 дә архив хезмәткәрләре тарафыннан 50 дән артык очерклар һәм документлар җыентыклары әзерләнә һәм нәшер ителә; алар арасында — «Татарстан большевиклары чит илләр интервенциясе һәм Гражданнар сугышы елларында» («Большевики Татарии в годы иностранной военной интервенции и Гражданской войны», 1961), «Татарстан Бөек Ватан сугышы

елларында» («Татария в годы Великой Отечественной войны», 1963), «Татарстан АССР-ны индустрияләштерү» («Индустриализация Татарской АССР», 1968), «Халык бәхете өчен көрәшүчеләр» («Борцы за счастье народное», кн. 1, 1967; кн. 2, 1983; кн. 3, 1988), «Кайтарылган исемнәр» («Возвращённые имена», 1990). Архив җитәкчеләре: С.С.Гафуров (1929–35), Я.С.Кормухин (1935–49), С.П.Люшин (1950–53), А.И.Лебедева (1953–67), М.Б.Кочурова (1967–77), Г.К.Касыймов (1977–85), Д.Р.Шәрәфетдинов (1986–91), Н.В.Юсупова (1992–2006), В.Г.Хәмидуллина (2006 дан).

*Әд.:* Центральный государственный архив историко-политической документации Республики Татарстан: Путеводитель. М., 1999.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ТЕА́ТР ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ́ БЕРЛЕГЕ́** (ТР ТЭБ), респ-ка театрлары хезмәткәрләрен берләштерүче, театр хезмәткәрләренең проф. осталыкларын күтәрү, яшь актёрларга, режиссёрларга, театр рәссамнарына идея-иҗади тәрбия бирү өчен төзелгән иҗтимагый оешма. Театр хезмәткәрләренең проблемаларын хәл итү, аларның эшләре һәм яллары өчен кирәкле матди шартлар тудыру ш.у. ТР ТЭБнең мөһим бурычларыннан берсе булып тора. 1938 елда оешкан Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлегеннән башлангыч ала. 1988 дән, Бөтенроссия театр җәмгыятен «Театр эшлеклеләре берлеге» (ТЭБ) итеп үзгәртү сәбәпле, РФ Театр эшлеклеләре берлегенең Татарстан бүлеге дип атала башлый; 2001 дән хәзерге исемендә. Берлекнең югары идарә органы булып ТР театр эшлеклеләре съезды санала, башта ул — 5 елга бер, 1988 дән 2 елга бер тапкыр җыела, съездлар арасында җитәкчелек чираттагы съезда сайланган идарә тарафыннан гамәлгә ашырыла. ТР ТЭБ театр хезмәткәрләренә проф. белем бирүне, семинарлар, конференцияләр, тамашачылар һәм тәнкыйтьчеләр б-н иҗади очрашулар үткәрүне оештыра; ТР Мәдәният министрлыгы уздырган бәйрәм чараларында, ш.и. К.Тинчурин исем., «Нәүрүз» һ.б. театр фестивальләрен оештыру һәм уздыру эшендә актив катнаша. ТР ТЭБ каршында *Актёрлар йорты*, архивлы китапханә, «Актёр» ял базасы (1964 тән) эшли. Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсенең беренче рәисе — актёр Д.Р.Любин (1938–41), соңрак — Х.Г.Әбҗәлилов (1941–54), Н.С.Гайнуллин (1954–63), М.З.Булатова (1963–71), Р.Г.Җиһаншина (1971–88), Р.А.Тажетдинов (1988–2011); 2011 дән – Ф.Р.Бикчәнтәев.

*Әд.:* Казань: Спец. вып. 2002. № 3/4.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ТӨЗЕЛЕ́Ш ҺӘМ АРХИТЕКТУ́РА ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**, к. *Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ «ТР ХАЛЫКЛАРЫ́ ТЕЛЛӘРЕ́ ТУРЫНДАГЫ́ ЗАКОН»НЫ́ ГАМӘЛГӘ́ КЕРТҮ́ КОМИТЕТЫ́**. 1994 елның июлендә ТР МК каршында җәмәгать башлангычында даими эшләүче орган буларак оеша. Максатлары: «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы Законның (1992 нең июлендә кабул ителә) һәм ТР халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программаларының үтәлешен контрольдә тоту; министрлыклар, ведомстволар, җирле үзидарә органнары, Татарстан шәһәр һәм район администрацияләре каршындагы шундый ук комиссияләр эшчәнлеген координацияләү, алар тарафыннан респ-каның уку йортларына гамәли, методик һәм консультатив ярдәм күрсәтү. Ком-т б-н ТР Премьер-министры җитәкчелек итә; аның составына министрлыклар һәм ведомстволарның җитәкчеләре, җирле хакимият органнары рәисләре, халык депутатлары, тел галимнәре керә. Иң элек 3 эш комиссиясе — терминология, топонимика һәм тел хезмәте күрсәтү комиссияләре оеша. 1999 ның октябреннән 7 комиссия — терминология, ономастика, халыкка татар телен өйрәтү, рус телен һәм башка милләтләр (татарлардан кала) телләрен өйрәтүне камилләштерү, чит телләр өйрәтү, тел сәясәтен компьютер технологияләрендә гамәлгә ашыру, татар телен куллануны тәртипкә салу буенча комиссияләр төзелә.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ТРАДИЦИО́Н МӘДӘНИЯТНЕ́ ҮСТЕРҮ́ ҮЗӘГЕ́**, ТР Мәдәният министрлыгы каршында. Традицион һәм хәзерге заман халык иҗатын үстерү, традицион бәйрәмнәрне, гореф-гадәтләрне, йолаларны, һөнәр-кәсепләрне, үзешчән сәнгатьнең барлык жанрларын тергезү буенча оештыру-методик, мәгълүмат туплау һәм координацияләү эшләре алып бара. 1939 елда Халык иҗаты йорты буларак оеша, 1979 дан Татарстан Респ-касының халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре фәнни-методик үзәге, 2011 дән хәзерге исемдә. 2011 дә Татарстан Респ-касының халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре фәнни-методик үзәге Татар фольклорын җыю, саклау, өйрәнү һәм пропагандалау дәүләт үзәге б-н берләштерелә. ТР халкына, РФ һәм башка илләрдә, ш.и. чит илләрдә яшәүче татар диаспорасына хезмәт күрсәтә. Респ-ка, төбәкара, зона смотрлары, фестивальләр, концертлар, бәйрәмнәр, ш.и. «Уйнагыз, гармуннар» («Играй, гармонь»), «Татар җыры», «Рус җыры» («Русская песня») бәйрәм концертлары, ТР шәһәрләре һәм районнарының иҗади хисапларын, ш.у. үзешчән халык иҗаты коллективлары җитәкчеләре өчен гамәли дәресләр, иҗат лаб-яләре, конференцияләр оештыра. 1990 елларда ТР халыкларының «*Каравон*», «*Уяв*», «Гырон Быдтон», «Семык», «Балтай», «Питрау бәйрәме» кебек традицион бәйрәмнәре кабат тергезелә. Үзәк эшчәнлегендә төрле вакытта С.Сәйдәшев, Җ.Фәйзи, З.Хәбибуллин, Н.Җиһанов, Б.Мөлеков, Ш.Сарымсаков һ.б. актив катнаша.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ТУРИ́ЗМ ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**, ТР Президентының 2014 ел 3 март Указы нигезендә *Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының* берничә бүлеге нигезендә ТРда туризм агентлыгы буларак оештырыла, ТР Президентының 2014 ел 20 март Указы һәм ТР МК, ТР Дәүләт Советының 2014 ел 20 март карарлары б-н — хәзерге исемендә. Татарстанда туризм һәм туризм индустриясе өлкәсендә дәүләт җитәкчелеген гамәлгә ашыра. Үз эченә туризм эшчәнлеген дәүләт күләмендә көйләү, туризм продуктын алга җибәрү, туризмны үстерү, дәүләт программаларын үстерү һәм гамәлгә ашыру, бухгалтер исәп-хисабы һәм дәүләт заказы бүлекләрен; кадрлар һәм хокукый эшләр секторларын ала. ТР Президентына һәм ТР МКна буйсына.

Рәисе – С.Е.Иванов (2014 тән).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ УЙЛА́П ТАБУЧЫЛА́Р ҺӘМ РАЦИОНАЛИЗА́ТОРЛАР ҖӘМГЫЯТЕ́**, 1991 елның 21 июнендә Гамәлгә кую съездында оештырыла. Бөтенсоюз Профсоюзлар үзәк советы Президиумының (ВЦСПС) 1958 ел 17 гыйнвар карары нигезендә төзелгән Бөтенсоюз уйлап табучылар һәм рационализаторлар җәмгыятенең (ВОИР) Татарстан өлкә оешмасы (1958 нең 8 августында оеша) дәвамчысы. Җәмгыятьнең төп максатлары: эшчеләрне, инженер-техник хезмәткәрләрне уйлап табуларга һәм рационализаторлыкка актив катнаштыру; уйлап табуларны һәм рационализаторлыкны көчәйтү. Җәмгыятьнең Татарстан өлкә һәм җирле советлары пр-тие һәм учреждениеләрдәге башлангыч оешмалары аша ярышлар, смотрлар, тематик конкурслар, үзешчән авторларның күргәзмәләрен, Җәмгыять активын һәм белгечләрне уйлап табу һәм рационализаторлык мәсьәләләре буенча укытуны, башка төбәк уйлап табучылары б-н иҗади тәҗрибә уртаклашуларны оештыралар, сәнәгый тәҗрибә үрнәкләрен ясаганда матди ярдәм күрсәтәләр. 1960–70 елларда оештыру-массакүләм чаралар даими үткәрелә башлый, рационализаторлык эше а.х.нда, төзелештә, азык-төлек сәнәгатендә дә активлаша. Иң мөһим мәсьәләләрне хәл итү өчен респ-ка пр-тиеләрендә 2300 иҗади комплекс һәм 310 иҗтимагый-конструкторлык бригадасы (1963) төзелә, аларда 10 меңнән артык кеше исәпләнә. 1965 тә җәмгыятьнең Татарстан өлкә советында Татарстан патентлар ин-ты ачыла (1992 дән — Патент белгечләре һәм пр-тиеоешмаларда уйлап табулар һәм рационализаторлык эшен оештыручылар әзерләү курслары), һәм ул 1965–92 еллар эчендә пр-тиеләрнең патент хезмәте өчен 2 меңнән артык белгеч әзерли. 1958–87 дә рационализаторлык тәкъдимнәре һәм уйлап табу турында белдерүләр ясаучы авторлар саны респ-када 33 меңнән 84,6 меңгә кадәр арта, гамәлгә кертелгән рационализаторлык тәкъдимнәре саны 24,5 меңнән 68 меңгә, уйлап табулар 40 тан 749 га (1975 тә 1185), алардан алынган файда 58 млн.нан 153,4 млн. сумга кадәр җитә. Җәмгыятьнең Татарстан оешмасы респ-ка халык хуҗалыгының фәнни-техник үсешенә зур өлеш кертә, ВЦСПСның, ВОИР Үзәк советының Мактау грамоталары, Бөтенсоюз соц. ярышларының дипломнары, күчмә вымпеллары б-н бүләкләнә. 1990 еллардан ТР У.т.һ.р.ж. төп игътибарны методик-оештыру эшләренә, белгечләрне өйрәтүгә һәм

аларның квалификациясен күтәрүгә, рационализаторлык һәм уйлап табуларга караган мәсьәләләргә хокукый һәм матди ярдәм күрсәтүгә, мәктәпләрдә һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрендә балаларның техник иҗатын үстерүгә юнәлтә. Җәмгыять «Уйлап табарга өйрән» («Учись изобретать», 1998, 2016), «Татарстан Республикасында уйлап табулар» («Изобретательство в Республике Татарстан», 2001), «Үзенчәлекле эшләнмәләрдән — уйлап табуларга» («От оригинальных самоделок — к изобретательству», 2004), «Яшь уйлап табучыларга» («Юным изобретателям», 2015) басмаларын, «Яшь уйлап табучы китапханәсе» («Библиотека юного изобретателя», 2007) сериясеннән 9 китап нәшер итә; «Лучшие изобретения года» бюллетене, «Изобретатель» г-тасы чыга. 2015 тә ТРда 21,7 мең кеше рационализаторлык тәкъдиме һәм уйлап табу турында гариза кертә; 41,2 мең рационализаторлык тәкъдиме һәм 1320 яңа уйлап табу файдаланыла; икътисади отыш 13,7 млрд. сум тәшкил итә.

ТР У.т.һ.р.җ. — «ТР предприятие, оешма һәм учреждениеләре арасында уйлап табу, рационализаторлык һәм патент-лицензия эшенең иң яхшы куелышы», «XXI гасыр кулибиннары», «Елның иң яхшы табышы», «ТР сәнәгать предприятиеләрендә — яшьләр», «Студентлар, аспирантлар һәм яшь галимнәр арасыннан иң яхшы уйлап табучы», «Яшьләр арасында ТР уйлап табучылары һәм рационализаторлары җәмгыяте премиясе лауреаты» конкурсларының төп оештыручысы. 2016 да җәмгыять тарафыннан студентлар һәм аспирантлар өчен ТР ФАнең акад. И.Б.Хәйбуллин исем. стипендиясе булдырыла.

Уйлап табучылар һәм рационализаторлар җәмгыятенең өлкә һәм респ-ка советы рәисләре: Е.И.Столбова (1958–61), В.И.Чепегин (1961–74), Р.К.Кәримов (1974–77), В.В.Чемерчев (1978–93), М.Ю.Әюпов (1993–2010), Л.Г.Гайсин (2010 нан).

*М.Ю.Әюпов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ҮЗӘ́К ФӘННИ́ ҺӘМ ҖӘМӘГА́ТЬ КИТАПХАНӘСЕ́**. 1931 елның 2 яртысында *Татарстан икътисад фәнни-тикшеренү институты* китапханәсе җирлегендә оеша. 1931 нең ноябрендә укучыларга системалы хезмәт күрсәтә башлый. Фондын, башлыча, Окт. рев-циясеннән соң бетерелгән яки үзгәртеп оештырылган Казан учреждениеләре һәм оешмаларының китап тупланмалары, ш.и. Казан руханилар академиясе китапханәсенең зур өлеше тәшкил итә. 1932 нең гыйнварыннан РСФСРда нәшер ителгән басмаларның түләүсез экземплярларын ала. Үз вакытында фондының зурлыгы б-н Казандагы иң зур китапханә санала (1 млн.нан артык берәмлек, күбесенчә эшкәртелмәгән). Китапханәдә Г.М.Бичурин (директор), М.А.*Васильев*, Г.М.Залкинд, Г.А.Скопин, А.Х.Хәбибуллин һ.б. хезмәт куя. 1932 нең августында Казан ун-ты китапханәсе б-н берләштерелә (к. *Казан университетының фәнни китапханәсе*).

*Әд.:* Р о м а н о в Я.С. Краткий очерк истории Научной библиотеки Татарской республики при Казанском государственном университете, 1804–1939. К., 1940; Научная библиотека Казанского университета в лицах. Ч. 1. Сотрудники библиотеки, 1806–2007 гг. К., 2011.

*В.И.Шишкин.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ФАЙДАЛЫ́ КАЗЫЛМАЛА́Р ЗАПАСЫ́ БУЕНЧА́ КОМИ́ССИЯСЕ**, к. *Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ФӘН ҺӘМ ТЕ́ХНИКА ӨЛКӘСЕНДӘГЕ́ ДӘҮЛӘ́Т БҮЛӘГЕ́**. ТР Президентының 1993 ел 16 апрель Указы б-н гамәлгә кертелә. Аерым затларга яки авторлар коллективына гуманитар, табигыять һәм техник фәннәр өлкәсендә ил һәм дөньякүләм дәрәҗәдәге, социаль-икътисади һәм рухи үсешкә этәргеч булучы казанышларга ирешкән; ресурсларны янга калдыруга юнәлдерелгән, экологик чиста яңа технологияләр һәм техника, дөнья аналогларына тиң материаллар эшләгән һәм гамәлгә керткән; фән һәм техника казанышлары нигезендә аеруча зур җитештерү нәтиҗәләренә ирешкән, яңа продукция төрләре уйлап тапкан өчен бирелә. ТРның Фән һәм техника өлкәсендә дәүләт бүләкләре комиссиясе тәкъдиме белән елга бер тапкыр ТР Президенты тарафыннан, бүләкләнүчеләргә лауреат исеме бирелеп, күкрәк билгесе һәм диплом б-н бергә тапшырыла. 2016 елның 1 гыйнварына бу исемгә 894 кеше лаек була.

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ФИ́ЗИК КУЛЬТУ́РА, СПОРТ ҺӘМ ТУРИ́ЗМ ДӘҮЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**. ТАССР ХКСның 1923 ел 2 сентябрь карары нигезендә ТАССР ХКС каршындагы (1925 тән — ҮБК каршындагы) Югары физик культура советы буларак оештырыла; ТАССР ХКСның 1936 ел 2 ноябрь карары б-н — ТАССР ХКС (1946 дан МС) каршындагы Физик культура һәм спорт эшләре ком-ты, ТАССР МСның 1953 ел 23 июнь карары б-н ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының физик культура һәм спорт бүлеге итеп үзгәртелә, ТАССР МСның 1954 ел 16 апрель карары б-н кабаттан ТАССР МСның Физик культура һәм спорт ком-ты итеп торгызыла, ТАССР МСның 1959 ел 9 гыйнвар карары б-н — ТАССРның Спорт җәмгыятьләре һәм оешмалары берлеге советы, ТАССР МСның 1968 ел 18 декабрь карары б-н — ТАССР МС каршындагы Физик культура һәм спорт ком-ты, ТАССР ЮС Президиумының 1986 ел 17 июль Указы б-н — ТАССРның (1992 дән — ТРның) Физик культура һәм спорт буенча Дәүләт ком-ты итеп үзгәртелә, ТР Дәүләт Советының 1996 ел 9 декабрь карары б-н — ТРның Физик культура, спорт һәм туризм дәүләт ком-ты. Физик культура, спорт һәм туризм өлкәсендә тармакара һәм терр. килештерү һәм көйләү эшләрен гамәлгә ашыра. Үз эченә секретариатны, үзәк бухгалтерия, оештыру һәм туристлык бүлекләрен ала. Дәүләт ком-ты системасына Үзәк спорт клубы; Спорт сарае; фехтование, футбол («Рубин»), көрәш («Батыр»), стендка ату, алкалы хоккей буенча респ-ка махсус олимпия резервы балалар-яшүсмерләр мәктәпләре; Р.Г.Нәҗметдинов исем. үзәк махсус олимпия резервы балалар-яшүсмерләр шахмат мәктәбе; «Маяк» уку-укыту спорт базасы (Яшел Үзән ш.) һ.б. керә. ТР Президентына, ТР МК һәм РФнең физик культура һәм туризм буенча дәүләт ком-тына буйсына. ТР Дәүләт Советының 2001 ел 11 май карары нигезендә гамәлдән чыгарыла, вазифалары *Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына* тапшырыла. Рәисе — Х.М.Мортазин (1986–2001).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ХАЛЫ́К АРТИСТЫ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1940 ел 1 февраль Указы б-н гамәлгә кертелә. Нигездә, исем 1939 дан бирелә башлый. ТР Президенты тарафыннан (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) сәнгать өлкәсендәге казанышлары өчен артистлар, режиссёрлар, балетмейстрлар, композиторлар, дирижёрлар, хормейстерлар, музыкантларга бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 395 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ХАЛЫ́К РӘССАМЫ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1948 ел 7 декабрь Указы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан сынлы сәнгать, скульптура, графика, гамәли-бизәлеш, театр, кино һәм телевидение сәнгатен үстерүдәге казанышлары өчен сынлы сәнгать эшлеклеләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына әлеге исемгә 57 кеше лаек була.

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ХАЛЫ́К УКЫТУЧЫСЫ́**, мактаулы исем. ТРның 2004 ел 24 март Законы б-н гамәлгә кертелә. ТР Президенты тарафыннан укытучылар һәм башка мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренә мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 3 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ХАЛЫ́К ШАГЫЙРЕ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1985 ел 9 сентябрь Указы нигезендә гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан әдәбиятны үстерүдәге казанышлары өчен шагыйрьләргә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 14 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ХАЛЫ́К ЯЗУЧЫСЫ́**, мактаулы исем. ТАССР ЮС Президиумының 1985 ел 9 сентябрь Указы нигезендә гамәлгә кертелә. ТР Президенты (1991 гә кадәр — ТАССР, ТССР ЮС Президиумы) тарафыннан әдәбиятны үстерүдәге казанышлары өчен язучыларга (драматургларга, прозаикларга), кинодраматургларга, әдәбият белгечләренә бирелә. Мактау грамотасы һәм күкрәк билгесе б-н бергә

тапшырыла. 2015 нең 1 гыйнварына бу исемгә 15 кеше лаек була.

**ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ХЕЗМӘ́Т ҺӘМ ХАЛЫКНЫ́ ЭШ БЕЛӘ́Н ТӘЭМИ́Н ИТУ́ ДӘУЛӘ́Т КОМИТЕТЫ́**, к. *Татарстан Республикасы Хезмәт һәм мәшгульлек министрлыгы*.

**ТАТАРСТА́Н СОВЕ́Т СОЦИАЛИ́СТИК РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ДӘУЛӘ́Т СУВЕРЕНИТЕТЫ́ ТУРЫНДА́ ДЕКЛАРА́ЦИЯСЕ**, конституцион әһәмияткә ия сәяси-хокукый акт, Татарстан тарихында яңа этапка башлангыч булып тора. 1990 елның 30 августында ТАССР ЮС тарафыннан кабул ителә. 6 маддәдән тора. Декларация б-н респ-каның дәүләт суверенитеты игълан ителә, һәм Татарстан Автономияле Совет Социалистик Респ-касы (ТАССР) Татарстан Совет Социалистик Респ-касы (ТССР) итеп үзгәртелә. Документ нигезендә, җир, җир асты һәм табигый байлыклар һ.б. ресурслар фәкать респ-ка халкының милке санала. Декларация Татарстан терр-ясендә яшәүче барлык гражданнарга, милләтенә, социаль чыгышына, диненә, сәяси карашларына һ.б. аерымлыкларына карамастан, тигез хокуклар һәм ирекләр, ш.у. дәүләт телләре буларак, татар һәм рус телләренең тигез кулланылышын, респ-кадагы башка халыкларның телләрен саклау һәм үстерүне гарантияли (к. *Татарстан Республикасы дәүләт телләре*).

Декларациядәге төп фикерләр 1992 елда кабул ителгән *Татарстан Республикасы Конституциясенең* һәм ТРда гамәлдә булган законнарның нигезен тәшкил итә. Декларация кабул ителгән көн Татарстан Респ-касы барлыкка килгән көн дип игълан ителә һәм бәйрәм көн булып исәпләнә (к. *Татарстан Республикасында бәйрәм көннәре*).

Ш.у.к. *«Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында шартнамә»*.

*Әд.:* Правовой статус Республики Татарстан. К., 1996. Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999.

*Б.Л.Железнов.*

**«ТАТАРСТА́Н СОВЕТЛАРЫ́»**, ТАССР ҮБК һәм Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның Казан шәһәр советы журналы. 1932, 1935 елларда Казанда чыга. 1932 елда — татар һәм рус телләрендә, 1935 тә татар телендә генә басыла. Беренче саны 1932 нең маенда дөнья күрә. Төрле еллардагы баш мөхәррирләре: Р.Насыйров, М.Яһүдин, Х.Кәримов, Т.Әюпов. Җирле советлар хезмәткәрләрен дәүләт төзелешенең актуаль мәсьәләләре б-н таныштырып бару, ш.у. киң катлам укучыларның игътибарын бөтен дәрәҗәдәге советлар эшенә, советларның массачыл оешмалары эшчәнлегенә җәлеп итү максатыннан нәшер ителә. Актив авторлары арасында — А.Болтушкин, Н.Исхаков, Х.Кәримов, Р.Насыйров. Респ-ка җитәкчеләренең (ш.и. ТАССР ҮБК Президиумы рәисләре М.Г.Яһүдин, Г.Г.Байчурина, ТАССР Халык комиссарлары советы рәисе К.А.Абрамов, ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре М.О.Разумовның) совет төзелеше өлкәсендәге күрсәтмәләре карашларын чагылдырган мәкаләләре, советларның икътисад һәм мәдәният өлкәсендәге эшчәнлеге турындагы язмалары басыла. Дәүләт аппараты кадрларын *төпләндерү* һәм эш кәгазьләрендә татар телен куллану проблемалары яктыртыла.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«ТАТАРСТА́Н» СОВХОЗЫ́** посёлогы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ургыды елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 2689 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 59%, руслар — 37%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, китапханә. Мәчет. 1929 да нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чаллы кантоны Яр Чаллы волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1938 дә — 253, 1949 да — 209, 1958 дә — 160, 1970 тә — 83, 1989 да — 2559, 2002 дә — 2607 кеше.

**ТАТАРСТА́Н СӨТ КООПЕРА́ЦИЯСЕ БЕРЛЕГЕ́** (Татмаслосоюз). 1929 елның маенда Казанда оештырыла. Элекке А.х. кредит-кәсепчелек берлегенең (1926) сөт җитештерү секциясе җирлегендә барлыкка килә. Сөт кооперативлары эшчәнлеген берләштерә. 1930 ның мартында Татарстан терлекчелек берлеге б-н кушыла һәм исеме Татарстан сөт һәм терлекчелек берлеге дип үзгәртелә.

**«ТАТАРСТА́Н СӨТЕ́» ПРЕДПРИЯ́ТИЕСЕ**, к. *Сөт һәм сыр-май җитештерү сәнәгате*.

**ТАТАРСТА́Н ТӨБӘКЛӘРЕ́Н ӨЙРӘНҮ́ БЮРОСЫ́**. 1925 елның маенда Татарстанда төбәкләрне өйрәнү эшен җитәкләүне координацияләү өчен *Гыйльми үзәк* каршында оештырыла. Рәисе – Г.Г.*Ибраһимов*, рәис урынбасары – В.Ф.*Смолин*, Г.Ф.Линсцер, сәркәтибе – Г.Зәйнуллин. 1927 нең февралендә ТАССР Мәгариф халык комис-ты коллегиясе «Татарстан Мәгариф халык комиссариатының Гыйльми үзәк каршында төбәкләрне өйрәнү бюросы турындагы нигезләмә»не, «Татарстан Мәгариф халык комиссариатының Гыйльми үзәк каршында төбәкләрне өйрәнү бюросының кантон һәм район бүлекләре турында нигезләмә»не раслый. 1925 нең май–июнь айларында Бюро төбәкләрне өйрәнү эшләрен оештыру һәм мәктәптә төбәкне өйрәнү мәсьәләләренә багышланган төбәкләрне өйрәнү конференциясе уздыра, анда 700 гә якын кеше катнаша. Бюроның төп эше экскурсияләр оештырудан гыйбарәт була. 1926 да экскурсия базасы оештырыла, 1926 ның 18 маеннан 18 августына кадәр эшли: 65 экскурсия оештырыла, анда 1657 кеше катнаша. Профессорлар, югары уку йортлары укытучылары, музей хезмәткәрләре, студент-практикантлар экскурсия җитәкчеләре булалар. Бюро эше барышында төбәкне өйрәнүгә багышланган фәнни-популяр лекцияләр оештырыла; мәс., Н.-Б.З.Векслин «Татарстан Республикасының табигате, халкы һәм хуҗалыгы» («Природа, население и хозяйство Татреспублики»), В.М.Ермолаев «ТАССРның авыл хуҗалыгы» («Сельское хозяйство ТАССР») темалары буенча лекцияләр укыйлар. Бюро һәрдаим Археол., тарих һәм этнография җәмгыяте, Татар халкы тарихын өйрәнү фәнни җәмгыяте, «Табигать сөючеләр» түгәрәге б-н үзара бәйләнештә тора. Төбәкне өйрәнүчеләр бюро җитәкчелеге ярдәмендә урыннарда археол. һәм тарихи-архит-ра истәлекләрен табу һәм саклау, торак пунктлар тарихын өйрәнү б-н шөгыльләнә. Респ-ка кантоннарында Т.т.ө.б. кысаларында 21 оешма, ш.и. төбәкне өйрәнүче түгәрәкләр, оешмалар һәм музейлар (Арча, Алабуга, Мамадыш, Тәтеш, Зөя, Чистай шәһәрләрендә) эшли. Бюро басмалары арасында




Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросының «Татарстанны өйрәнү материаллары» җыентыгы. 1925.

«Татарстанны өйрәнү материаллары» («Материалы по изучению Татарстана», 1925, 2 чыг.), Н.Н.Фирсовның «Татарстанның үткәне» («Прошлое Татарии», 1926), В.Ф.Смолинның «Төбәкне өйрәнү кулланмасы» («Руководство по изучению края») хезмәтләре бар. 1928 нең августында Т.т.ө.б. эшчәнлеге туктатыла һәм аның җирлегендә *«Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте»* барлыкка килә.

*Әд.:* Зайцев А.В. Исторические учреждения Республики Татарстан в 20–30-е годы XX века. К., 1998; Фаттахова Г.А., Валеев Р.К. Академический центр Татарии: 1920-е годы. К., 2002.

**ТАТАРСТА́Н ТӨЗЕЛЕ́Ш МАТЕРИАЛЛАРЫ́ ҺӘМ МЕТА́ЛЛ ЭШКӘРТҮ́ КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́ КООПЕРАТИВЛАРЫ́ БЕРЛЕГЕ́** (Татстройметаллпромсоюз). 1954 елның декабрендә Казанда оештырыла. Татарстан төзелеш материаллары һәм Татарстан металл эшкәртү кәсепчелеге кооперативлары берлекләре җирлегендә барлыкка килә. Максаты – төзелеш өчен кирәкле җиһаз һәм материаллар җитештерүне арттыру, аларны сатуны оештыру, инвалидлар өчен эш урыннары булдыру. 28 артельне берләштерә. *Татарстан кәсепчелек кооперативлары советына* буйсына. 1956 ның октябрендә эшчәнлеге туктатыла.

**ТАТАРСТА́Н ТӨ́РЛЕ КӘСЕПЧЕЛЕКЛӘ́Р БЕРЛЕГЕ́**. 1932 елның маенда Казанда төзелә. 30 артельне берләштерә. Төп максаты — артельләрнең җитештерү һәм финанс эшчәнлегенә җитәкчелек итү. *Татарстан кә-*

*сепчелек кооперативлары советына* буйсына. 1952 нең августында — Казан өлкә кәсепчелекләре берлеге (Казоблмногопромсоюз), 1953 нең апрелендә Татарстанның күпләгән кәсепчелекләр берлеге (Татмногопромсоюз) дип үзгәртелә. 1957 дә бетерелә.

**ТАТАРСТА́Н УРМА́Н-ТӘҖРИБӘ́ СТА́НЦИЯСЕ**, Бөтенроссия урманчылык һәм урман хуҗалыгын механикалаштыру фәнни-тикшеренү ин-ты ф-лы. 1926 елда урман хуҗалыгы мәсьәләләрен фәнни һәм гамәли яктан тирәнтен өйрәнү максаты б-н Казан тәҗрибә урманчылыгы җирлегендә оештырыла. 1930 га кадәр ТАССР Җир эшләре халык комис-тының Урман идарәсе карамагында, 1930–36 да Үзәк сал агызу фәнни-тикшеренү ин-тының Идел-Кама ф-лы составында. Т.у.-т.с. составына 2003 тә — Имәнлекләрне өйрәнү буенча үзәк (Чабаксар ш.), 2006 да – Мари урманнарын өйрәнү фәнни-тикшеренү үзәге (Йошкар-Ола ш.), 2007 дә Боровой урман-тәҗрибә станциясе (Оренбург өлкәсе) керә. Төп тикшеренүләр урманчылык, селекция һәм орлыкчылык, фитопатология һәм урманнарны саклау өлкәсенә карый. Т.у.-т.с. галимнәре тарафыннан чыршы һәм ак чыршы урманнарында хуҗалык алып баруның, культурада һәм питомникларда ак чыршы үстерүнең яңа ысуллары нигезләнә; сәламәт, нык агачлар сайлап алына һәм Татарстан, Чуаш, Мордва, Мари респ-калары терр-ясендә төп урман ясаучы токымнарның генетик резервлары билгеләнә (СССР ВДНХсының көмеш медале, 1989); даими эшләүче урман-орлыкчылык участоклары һәм плантацияләре, урманнарны яңарту һәм карау максатыннан сайлап кисү системасы булдырыла, шуның нигезендә йөзләрчә гектар эталон урманнар барлыкка килә (К.В.Краснобаева); питомникларда ылыслы һәм яфраклы токымнарны үстерү һәм авырулардан саклауның интеграль системасы (Н.М.Ведерников, Н.С.Фёдорова), наратка эрбет ялгауның ялгам һәм ялганманың үзара сыешмавына юл калдырмый торган үзенчәлекле ысулы (Г.Ш.Камалтинов), төрле тополь клоннарының биол. үзенчәлекләрен өйрәнү нигезендә сәламәт усак үстерү алымнары (Н.В.Напалков, Е.Г.Баранчугов), комплекслы механикалаштыру җирлегендәге кисенделәрдә үсеп җиткән утырту материалы кулланып ылыслы токымнар культурасын булдыру ысуллары (Н.А.Миронов, Л.И.Майоров), зоналы-типологик нигездә урман хуҗалыгы эшләре алып бару алымнары (Ф.В.Әһлиуллин), корый башлаган имәнлекләрне яңарту ысуллары (А.И.Мурзов, Н.А.Кузнецов, В.П.Глебов, В.А.Петров), ерым-сыза системаларында һәм кече елга ярларында су эрозиясен чикләү буенча чаралар комплексы (Ч.С.Хәсәнкаев, И.Р.Уразов), Мари Респ-касында янган урманнарда һәм май коңгызы б-н зарарланган участокларда нарат урман культураларын тергезү системасы (Б.Г.Троицкий, Н.С.Лисов) эшләнә. Станция хезмәткәрләре тарафыннан тикшеренү һәм алдынгы тәҗрибәләр б-н уртаклашу өчен җирлек булып торучы 500 дән артык стационар тәҗрибә объекты, Яшел Үзән һәм Арча урман хуҗалыкларында нарат һәм чыршының геогр. культуралары, *Казан дендрарие, Эрбет паркы булдырыла; «Кишәнгер», «Фәхри яры», «囲Таштау»* (соңыннан табигать истәлекләре дип игълан ителәләр) участокларындагы ерымнарны ныгыту буенча урман-мелиорация эшләре үткәрелә. «Хезмәтләр...» («Труды...», 1936–70) басыла. Станциянең күп кенә хезмәткәрләре урманчылык белемендә һәм урман хуҗалыгында зур уңышларга ирешкәннәре өчен атказ. урман белгече исеменә лаек була: РСФСР(РФ) — Н.В.Напалков (1962), Г.Г.Мгебров (1967), Б.Г.Троицкий (1967), Ф.В.Әһлиуллин (1999); ТАССР (ТР) — А.А.Бобровский (1968), Ч.С.Хәсәнкаев (1983), Н.С.Фёдорова (2002); РСФСР (РФ) һәм ТАССР (ТР) — А.И.Мурзов (1972, 1987), Н.М.Ведерников (1977, 1997), К.В.Краснобаева (1986, 1997).

Т.у.-т.с. директорлары: Н.Н.Белькович (1926–31), М.А.Шишкин (1932–38), П.Г.Трошанин (1938–46), А.А.Бобровский (1946–60), А.А.Мурзов (1960–89), Н.А.Кузнецов (1989–2003), М.Н.Сухов (2003–08), И.Г.Ганиев (2008 дән).

2007 елда Т.у.-т.с.нең исеме Көнчыгыш Европа урман-тәҗрибә станциясе дип үзгәртелә.

*Әд.:* Бобровский А.А. Тридцать лет Татарской лесной опытной станции // Сб. тр. по лесному хозяйству. 1957. Вып. 13; Кузнецов Н.А., Ведерников Н.М. Татарской лесной опытной станции 75 лет // Проблемы лесного хозяйства Среднего Поволжья и пути их решения. К., 2001.

*С.Ю.Краснобаева.*

**«ТАТАРСТА́Н ХАТЫ́Н-КЫЗЛАРЫ́»**, иҗтимагый оешма. 1995 елның декабрендә оештырыла. Җитәкчесе — З.Р.*Вәлиева*. Максаты – иҗтимагый-сәяси, икътисади, социаль-мәдәни тормышта хатын-кызның ролен күтәрү; гаилә һәм балалар мәнфәгатьләрен яклау. Эшчәнлегенең төп юнәлеше — яңа социаль-икътисади шартларда хатын-кызның урынын өйрәнү, ятим балаларны кайгырту, күп балалы гаиләләрне яклау, хатын-кызлар өчен яңа эш урыннары оештыру, качак һәм күчеп килүче хатын-кызларга матди һәм мораль ярдәм күрсәтү. Оешмага Халык мәгарифе, сәламәтлек саклау һәм мәдәният өлкәсендә эшләүче хатын-кызлар ассоциациясе, Респ-ка балалар фонды, Ятимнәр хокукларын яклау фонды, Татарстан хатын-кыз эшмәкәрләр берлеге, Бөтентатар «Кызыл ярымай» җәмгыяте, Солдат аналары ком-ты, «Хатын-кызлар — Татарстан галимәләре» ассоциациясе, Татарстан иҗади берлекләре хатын-кызлары ассоциациясе, «Таяныч» эшсез калган хатын-кызлар һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү фонды, «Чишмә» тулы булмаган гаиләләр советы, «Аналар наркотикларга каршы» бөтенроссия хәрәкәтенең төбәк бүлеге, Мөселман хатын-кызлары ассоциациясе керә. Ш.у.к. *Хатын-кызлар хәрәкәте.*

**«ТАТАРСТА́Н ХӘБӘРЛӘРЕ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. Оештыручылары — ТР Дәүләт Советы һәм ТР МК, 1995 елның маеннан — газета редакциясе коллективы. 1991 нең 14 августыннан 1995 нең 30 июненә кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә, барысы 883 саны чыга. Мөхәррирләре — Р.М.*Харисов*, 1995 нең июненнән З.М.*Мансуров*. Күренекле журналистлар арасында — И.Әхмәтҗанов, Г.Шәмсетдинов, И.Хәйруллина, Ф.Тарханова, М.Гәрәев, С.Кашапова, Х.Бәдретдинов. Газета ТР Президенты Указларын, ТР Дәүләт Советы кабул иткән законнар һәм карарларны бастыра, Татарстанның иҗтимагый-сәяси һәм социаль-икътисади тормышын яктырта. Атнаның «Җомга» санында мәдәният һәм сәнгать мәсьәләләренә киңрәк урын бирелә. «Туган тел», «Җан азыгы», «Сихәт», «Икәүдән-икәү» һ.б. махсус сәхифәләр дөнья күрә. Төп рубрикалары: «Татар халкынниләр борчый, ниләр шатландыра», «Язмышлар язылганда» һ.б. Редакция ТРның дәүләт символларын сайлау мәсьәләсе буенча киң колачлы дискуссия оештыра. 1995 нең июленнән «Т.х.» г-тасы җирлегендә «*Мәдәни җомга*» г-тасы чыга башлый.

**ТАТАРСТА́Н ХӘРБИ́ КОМИССАРИАТЫ́**, РФ Оборона министрлыгы хәрби идарәсенең җирле органы. Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна советы гомуми җыелышының 1918 ел 26 февраль карары б-н Казан Совет Эшче-Крәстиян Респ-сының Хәрби эшләр комис-ты буларак оештырыла. ХКСның 1918 ел 8 апрель Декреты, Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан губерна советы башкарма ком-тының 1918 ел 3 июнь карары һәм Казан губернасы ХКСның 1918 ел 16 май карары б-н Казан губерна Хәрби эшләр комис-ты дип үзгәртелә; Бөтенроссия ҮБК һәм РСФСР ХКСның 1920 ел 27 май Декреты һәм Респ-ка РВСының 1920 ел 4 сентябрь боерыгы б-н ТАССР (1990 нан — ТССР, 1992 дән — ТР) Хәрби комис-ты дип үзгәртелә. РСФСР Хәрби һәм диңгез эшләре халык комис-тына (1918–23), СССР Хәрби һәм диңгез эшләре халык комис-тына (1923–34), СССР Оборона халык комис-тына (1934–46), СССР Оборона министрлыгына (1946–91) буйсына. Аның эшчәнлеге б-н турыдан-туры РФ Хәрби көчләр Ген. штабы (1918–21 дә Бөтенроссия баш штабы, 1921–35 тә Эшче-Крәстиян Кызыл Армиясе штабы, 1935–91 дә СССР Хәрби көчләре Ген. штабы), Идел буе (1918–41, 1943–45, 1946–89, 1992–2001), Мәскәү (1941–43), Казан (1945–46) һәм Идел буе-Урал (1989–92, 2001 дән) Хәрби округ гаскәрләре командующие җитәкчелек итә. Башта хәрби хезмәткә алынучыларны барлау, матди мөмкинлекләр, мобилизацион эшләр, часть һәм подразделениеләр оештыру, гаскәрдәгеләрне укыту һәм тәэмин итү б-н шөгыльләнә; өйрәнү җыеннары, күнегүләр һәм манёврлар үткәрә, мобилизацияләнгәннәрне озату, яралыларны дәвалау һәм әсирләрне тотуга күзәтчелек итә; җирле гаскәрләр, хәрби учреждениеләр, госпитальләр, хәрби милек б-н җитәкчелекне гамәлгә ашыра; 1930 еллар ахырыннан хәрби мобилизация уздыруга әзерли һәм аны үткәрә, кеше һәм халык хуҗалыгы ресурсларын барлый, яшьләрне хәрби хезмәткә әзерли, гражданнарны хәрби хезмәткә һәм өйрәнү җыеннарына алуны оештыра, башка оборона чаралары үткәрә; 1990 еллардан хәрби хезмәткә чакыруны җитәкли, 21 йөз башыннан контракт буенча хезмәткә алу, транспорт б-н тәэмин итү; запас-

та исәпләнгән гражданнар б-н практик дәресләр үткәрү, хәрби хезмәткә алынучыларны барлау һәм сәламәтлекләрен тикшерү; запаста исәпләнгән һәм хәрби хезмәткә алынырга тиешле гражданнарны хәрби теркәү б-н бәйле мәсьәләләрне хәл итә. Бөек Ватан сугышы елларында Комис-т тарафыннан фронтка, даими хәрби хезмәткәрләрне дә исәпләп, 700 меңгә якын кеше, Әфганстан Демократик Респ-касындагы хәрби операцияләрдә катнашу өчен 9750 кеше, Чечен Респ-касына 12,5 мең кеше алына һәм озатыла. Т.х.к. карамагында — өяз (1920 гә кадәр), кантон (1920–30), волость (1930 га кадәр), район (1930–2009) хәрби комис-тлары, 2009 дан — шәһәрләр һәм Татарстан районнары бүлекләре.

Хәрби комиссарлар: Н.Д.Ефремов (февр.– июль, 1918), И.И.Межлаук (июль–сент., 1918), С.К.Судьин (сент.–нояб., 1918), Д.Н.Авров (нояб., 1918–апр., 1919), Беляев (апр.–нояб., 1919), М.Б.Ительсон (нояб., 1919–1920), К.Г.Хахарев (1920–21), А.А.Алмаев (1921–23), П.Е.Ершов (1923–27), А.И.Метелев (1927–32), Х.П.Насыйров (1932–36), А.Д.Хәйруллин (1936–38), П.П.Рубанов (1938–41), А.Н.Евдокимов (1941–46), Т.П.Кругляков (1946–54), А.Д.Овсеенко (1954–59), С.Н.Саенко (1959– 1964), Л.И.Салюков (1964–66), П.И.Ключников (1966–78), В.П.Шварёв (1978–89), И.Д.Стогниев (1989–98), Р.Ш.Мостаев (1998–2005), С.Н.Погодин (2005 тән).

*Е.Б.Долгов.*

**ТАТАРСТА́Н ҺӘМ ТАТА́Р ХАЛКЫ́ ТАРИХЫ́Н ӨЙРӘНҮ́ ГЫЙЛЕМЕ́.** Татарларның борынгы бабалары — *болгарлар* турында беренче мәртәбә искә алу 5 йөзгә карый (тарихчы Приск Панийский хезмәте, 463 ел). Идел буе Болгар дәүләте һәм анда яшәүче халыклар турында җентекле мәгълүмат *Ибне Фазлан (Фадлан)* тарафыннан калдырыла (10 йөз). Болгарлар һәм төбәктәге башка халыклар турындагы күп кенә мәгълүматлар (терр-янең формалашуы, тел, дини күзаллаулар, риваятьләр, гореф-гадәтләр) 10–13 йөзләрдәге гарәп-фарсы һәм төрки авторлар *Ибне Рустә, Мәхмүд Кашгари, әл-Гарнати, Ибне әл-Әсир* һ.б. хезмәтләрендә бар. Идел буе Болгар дәүләте халкының ислам динен кабул итүе (922) болгарлар тарихын өйрәнүнең төп юнәлешен билгели. Мөселман традицияләре акрынлап борынгы төрки күзаллауларны кысрыклый һәм рәсми тарихны өйрәнү гыйлеме өчен нигез сала. Беренчеләрдән булып болгар тарихчысы *Ягъкуб бине Ногманның* «Болгар тарихы» китабында (11 йөз) үз халкы турында тарихи белемнәрне системалы бәян итү омтылышы ясала. Болгар галимнәре, дин әһелләре һәм язучылары *Кол Гали, Сөләйман бине Дауд әс-Саксини әс-Сувари*, Әбүл Галә Хәмид бине Идрис әл-Болгари, Борһанетдин Ибраһим бине Йосыф әл-Болгари, әл-Хәнәфи Борһанетдин Ибраһим бине Хозыр әл-Болгари, *Хаҗи Әхмәт әл-Болгари* һ.б. хезмәтләрендә астрономия, астрология, медицина, география, тарих, хокук, дини тәгълимат үсеше турында тарихи мәгълүматлар саклана.

Алтын Урда чорында рәсми тарихны өйрәнү гыйлеме традицияләре *Рәшидетдиннең* «Җыелма тарих» («Җамигъ әт-тәварих», 1311) хезмәтендә, аерым идарәчеләр шәҗәрәләрендә һәм фольклор традицияләрендә чагыла. *Сәйф Сараиның* «Китабе Гөлестан бит-төрки», *Мәхмүд Болгариның* «Нәһҗел-фәрадис» әсәрләрендә төрки-татар җәмгыятенең кайбер тарихи-фәлсәфи һәм дини мәсьәләләре карала. Көнбатыш Европа һәм гарәп сәяхәтчеләре Дж. *Карпини*, В. де *Рубрук, Юлиан, Ибне Баттута, Йәзди* Шәрәфетдин Гали, *әл-Максуди* һ.б.ның әсәрләрендә Алтын Урда ханнары, шәһәрләре, дине, теле, халкы, андагы һөнәрчелек үсеше турында мәгълүматлар бар.

Казан ханлыгы чоры тарихи фикере чагылган язма истәлекләр сакланмаган диярлек. Казан татарлары һәм Казан ханлыгы турында мәгълүматлар рус *елъязмаларында*, А.М.*Курбскийның* «Мәскәүнең бөек кенәзе турындагы тарих» («История о великом князе Московском») китабында,«Казан елъязмачысы» («Казанский летописец») хикәятендә, Европа сәяхәтчеләре С. фон *Герберштейн*, А.*Дженкинсон*, А.*Олеарий*, Д.*Флетчер* һ.б.ның хәбәрләрендә, аерым татар *шәҗәрәләрендә* һәм фольклор әсәрләрендә чагыла. Татар халкының урта гасырлар тарихына һәм мәдәниятенә бәйле бай мәгълүматлар *Әбелгазый Баһадур ханның* «Төркиләр шәҗәрәсе» («Шәҗәрә-и тюрк»), Шәриф Хаҗитарханиның «Зафар-намә-и вилайәт-и Казан» һ.б. әсәрләрендә теркәлгән.

Рус дәүләте Казан ханлыгын яулап алганнан соң (1552), татар тарихын өйрәнү гыйлеменең үсеше өзелә. Татар җәмгыяте турындагы кайбер мәгълүматлар бәетләрдә, дастаннарда, тарихи җырларда һәм халык иҗатының башка жанрларында, ш.у. аерым шәҗәрәләр һәм кабер ташлары язмаларында саклана. Безгә килеп җиткән татар тарихи әдәбиятының иң борынгы язма истәлекләре 17 йөзгә карый. Шуларның берсе — *Кадыйргали бәкнең* «Елъязмалар җыентыгы» («Җамигы әт-тәварих», 1602), анда тарихи вакыйгалар б-н беррәттән 16 йөз ахыры — 17 йөз башы мәскәүлеләр яклы рухтагы татар аксөякләренең карашлары күрсәтелә. *«Дәфтәре Чыңгызнамә»* әдәби-тарихи әсәре 1680 елларга карый, анда татар тарихы фикеренең 2 төрле — Болгар һәм Алтын Урда традицияләре үзара үрелә. 18 йөздә – 19 йөз башында *Шәрәфетдин бине Хисаметдин* әл-Мөслими әл-Болгари, Т.*Ялчыгол* һ.б.ның әсәрләре Идел буе Болгар дәүләте тарихына багышлана.

Төбәк тарихын өйрәнүгә рус тикшеренүчеләре сизелерлек өлеш кертә. Казан төбәге һәм татарлар турында кыйммәтле материаллар 18 йөздә *Академия экспедицияләрендә* катнашучылар И.И.*Лепёхин*, Г.Ф.*Миллер*, П.С.*Паллас* тарафыннан җыела. Татарлар турында тарихи-этнографик мәгълүматлар П.И.*Рычков*, И.И.*Георги* хезмәтләрендә бар. В.Н.*Татищев*, Н.М.*Карамзин*, С.М.*Соловьёв*, В.О.*Ключевский*, Н.И.Костомаровның Россия тарихы буенча гомумиләштерүче хезмәтләрендә татар халкының үткәне Россия дәүләте формалашу тарихы контекстында гына күрсәтеп үтелә. 19 йөздә – 20 йөз башында татар халкы тарихын өйрәнүгә Н.К.*Баженов*, И.Н.*Березин*, В.В.*Вельяминов-Зернов*, В.Н.*Витевский*, В.В.*Григорьев*, С.В.Ешевский, Н.П.*Загоскин*, П.Е.*Заринский*, И.А.*Износков*, А.Ф.*Лихачёв*, А.Ф.*Можаровский*, Г.И.*Перетяткович*, М.С.*Рыбушкин*, В.Г.*Тизенгаузен*, Н.А.*Фирсов*, Н.Н.*Фирсов*, К.Ф.*Фукс*, А.А.*Фукс*, И.И.*Хәлфин*, С.М.*Шпилевский*, А.Паркер һ.б. билгеле бер өлеш кертәләр. Алар тарафыннан зур күләмле фактик материал җыела, татар халкы тарихын өйрәнү гыйлеменең күп кенә аспектлары, ш.и. Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан һәм Касыйм ханлыклары, Идел буе һәм Урал алдындагы рус булмаган халыкларны колонияләштерү һәм христианлаштыру, 17–18 йөзләрдәге башкорт-татар күтәрелешләре, Казан губернасы авыллары, Казан тарихы тикшерелә. Алар ш.у. татар халкының тюркологиясен, археологиясен, этнографиясен, Шәрекъ (Алтын Урда) нумизматикасын өйрәнүгә зур өлеш кертәләр. Шулай да аларның хезмәтләрендә төбәк һәм татар халкы тарихы, нигездә, рәсми Россия тарихын өйрәнү гыйлеме кысаларында яктыртыла.

19 йөзнең 2 яртысында — 20 йөз башында Т.һ.т.х.т.ө.г. күтәрелеш кичерә, ул татарларның милли үзаңнары формалашып бетү б-н аңлатыла. 1880–90 елларда татар халкы тарихына бәйле беренче зур күләмле гомумиләштерелгән әсәр барлыкка килә. Ул — Ш.*Мәрҗанинең «Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар»* хезмәте. Анда бай чыганаклар материалы нигезендә Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм татар ханлыкларындагы мөселманнар тарихының дәвамлылыгы күрсәтелә, Россия империясе составында татар халкы тарихының социаль-икътисади, этномәдәни, дини һ.б. аспектлары карала. Х.*Әмирханов* һәм Х.*Фәезханов* хезмәтләрендә Идел буе Болгар дәүләте, Казан һәм Касыйм ханлыклары тарихы чагыла. Тарихи белемнәрне популярлаштыручы К.Насыйри үзе чыгарган татарча өстәл календарьларында болгарлар, Казан ханнары, борынгы Казан турында мәгълүматлар, риваятьләр урнаштыра. Ул ш.у. Идел алдының төньягындагы күп кенә авылларда яшәүчеләрнең болгарлар икәнен дәлилләүче Казан губернасы Зөя өязе авыллары килеп чыгышы турында риваятьләр һәм тарихи-эпиграфик материаллар җыя; беренчеләрдән булып Е.И.Пугачёв кузгалышы тарихына мөрәҗәгать иткән М.С.*Аитов* хезмәтен басмага әзерли.

20 йөз башында Т.һ.т.х.т.ө.г.ндә Р.*Фәхретдин* һәм *Морад Рәмзи* хезмәтләренең дөньяга чыгуы зур вакыйгага була. Р.Фәхретдин тарафыннан төзелгән «Асар» биобиблиографик җыентыгы Идел буе Болгар дәүләте дәвереннән алып 20 йөз башына кадәрге чордагы 1200 дән артык күренекле мөселман әһелләренең биографиясен үз эченә ала. Морад Рәмзи 2 томда басылган «Казанда вә Болгарда булган вакыйгалар һәм татар мәликләре турында хәбәрләр» («Тәлфыйк әл-әхбар вә тәлкыйх әл-асәр фи вәкаигъ Казан вә Болгар вә мөлүк әт-татар», 1908) исемле хезмәтендә татар халкы тарихын борын-

гы дәверләрдән алып һәм гомумтарихи процесс фонында өйрәнә, татар халкы тарихын өйрәнү гыйлеменең дәвамлылыгын күрсәтә.

20 йөз башында татар тикшеренүчеләренең игътибарын күбрәк татар халкының гомумтөрки үткәне кызыксындыра башлый. Х.*Габәшинең* «Төрки кабиләләрнең тулы тарихы» («Мөфассал тарих кауме төрк», 1909) хезмәтендә төрки халыкларның мәдәнияте, мәгарифе, фәне, хәрби эше һәм хуҗалык эшчәнлеге тарихы һәм аларның диннәре яктыртыла. Ә.*Вәлидинең* «Төрек вә татар тарихы» (1912) хезмәте киң җәмәгатьчелеккә таныла, замандашлары тарафыннан төрки халыкларның беренче гомуми тарихы буларак бәяләнә. Г.*Әхмәровның* төрки-татар дәүләтләре тарихына багышланган «Болгар тарихы» (1909) һәм «Казан тарихы» (1910) хезмәтләре ш.у. шушы чорга карый. Аларда ул әлеге дәүләтләрнең сәяси тарихы, икътисад һәм мәдәният үсеше, халыкларның дине, гореф-гадәтләре мәсьәләләрен тикшерә. Казан ханлыгы — Идел буе Болгар дәүләтенең дәвамчысы, ә Казан татарлары — борынгы болгарларның варислары булуына инанган Әхмәров татарларның дәүләт берләшмәләренең дәвамчылык идеясен яклап чыга. Ул ш.у. татар халкы этнографиясенең кайбер аспектларын («Мишәр халкы һәм теле турында», «Казан татарларының туй йолалары», «Типтәрләр һәм аларның килеп чыгышы») һәм татар археологиясен (Сувар шәһәренең урынын ача) үстерүгә зур өлеш кертә. Г.*Баттал* «Татар тарихы» (1912) хезмәтендә Идел буе Болгар дәүләтенең, Алтын Урданың һәм Казан ханлыгының тарихын нигезле анализлый. Татар ханлыклары тарихын ш.у. Һ.М.*Атласи* «Себер тарихы» (1911), «Сөембикә» (1914), «Казан ханлыгы» (1920) хезмәтләрендә тикшерә. Татар халкы тарихы һәм мәгърифәте Г.Баруди, К.Бикколов, Ә.Вәлиди, Җ.Вәлиди, Г.Гобәйдуллин хезмәтләрендә яктыртыла.

П.В.Знаменский, Я.Д.Коблов, Е.А.Малов, М.А.Машанов, Н.И.Остроумов һ.б. авторлар хезмәтләрендә Идел һәм Урал буенда яшәгән рус булмаган халыкларны христианлаштыру тарихы, миссионерлык эшчәнлеге, Казан руханилар академиясе, дини мәктәпләр, татарларның конфессиональ уку йортлары тарихының аерым аспектлары чагыла. Татарлар тарихын өйрәнү гыйлеме мәсьәләләре алар тарафыннан, башлыча, патша хөкүмәте гамәлләренең апологиясе позициясеннән чыгып тикшерелә.

1917 нең октябреннән Т.һ.т.х.т.ө.г.үсешендә яңа этап башлана. Тикшеренүчеләр 2 дәвергә — рев-циягә кадәрге һәм Октябрьдән соңгы чорларга бүленә, анда мөһим мәсьәләләр хронологик һәм тематик тәртиптә аерып карала. 1920 еллар ахыры — 1930 еллар башыннан тарихи тикшеренүләрнең методологик нигезен формация карашына нигезләнгән марксизм-ленинизм тәгълиматы тәшкил итә.

Татарстан АССР барлыкка килү б-н (1920) татарлар һәм төбәк тарихын өйрәнү яңа этәргеч ала. Төрле фәнни-тикшеренү үзәкләрендә һәм фәнни түгәрәкләрдә (*Гыйльми үзәк, Татар мәдәнияте йорты, Татарстан икътисад фәнни-тикшеренү институты, Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте, Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросы, Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте,* Казан ун-ты каршындагы *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* һ.б.) төбәк тарихын өйрәнүдә Б.Ф.*Адлер*, Җ.Вәлиди. Н.И.Воробьёв, В.М.*Горохов*, Г.С. һәм М.С.Гобәйдуллиннар, П.М.*Дульский*, В.М.Ермолаев, Г.Г.*Ибраһимов*, М.К.*Корбут*, Г.*Рәхим*, Н.Н.*Фирсов*, М.Г.*Худяков*, Г.Ш.*Шәрәф* һ.б. актив катнаша. М.Худяковның «Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар» («Очерки по истории Казанского ханства», 1923), Г.С.Гобәйдуллинның «Татар тарихы» (1923), Г.Сәгъдинең «Татар әдәбияты тарихы» (1926), Н.И.Воробьёвның «Казан татарларының матди мәдәнияте» («Материальная культура Казанских татар», 1930), В.И.Ермолаев, Г.Ш.Шәрәф, М.А.Хәсәновның «Татарстан Республикасының икътисади географиясе буенча очерклар» («Очерки по экономической географии Татреспублики», 1931) гомумиләштерелгән хезмәтләре татар халкы тарихын өйрәнү гыйлемендә күренекле вакыйга була. «Татарларның әдәбияты һәм мәгарифе тарихы очерклары (1917 елгы революциягә кадәр)» (М., 1923) хезмәтендә Җ.Вәлиди борынгы дәверләрдән алып татар рухи мәдәнияте тарихын чагылдыра. Мәгариф өлкәсендә патша хөкүмәте сәясәтенә карата тәнкыйди фикерләү В.М.Гороховның «Царизмның Идел буе татарларына карата реакцион мәктәп сәясәте» («Реакционная школьная политика царизма в отношении татар Поволжья», 1941) хезмәтендә бирелә. Шулай да тарих ф-тлары ябылу һәм югары уку йортларында тарих укытуга чик куелу Т.һ.т.х.т.ө.г. үсешенә тискәре йогынты ясый.

Бер үк вакытта Окт. рев-циясе һәм РКП(б) тарихы буенча комиссиянең Татарстан бүлеге (к. *Истпарт*) тарафыннан зур тикшеренү эше башкарыла, ул 1920 дә революцион хәрәкәт тарихын, Коммунистлар партиясе һәм аның Татарстан тарихындагы ролен өйрәнү өчен оештырыла. 19–20 йөзләрдә революцион хәрәкәт, большевиклар оешмалары барлыкка килүе һәм үсеше, Казан губернасында В.И.Ленин һәм аның көрәштәшләренең революцион эшчәнлеге тарихы һ.б. буенча бик күп мемуарлар һәм документаль материаллар җыела (документлар һәм истәлекләрнең бер өлеше бастырыла).

И.В.Сталинның шәхес культы Т.һ.т.х.т.ө.г. үсешенә зур зыян китерә. 1944 нең 9 августында ВКП(б) ҮК тарафыннан *«Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»* карар кабул ителә, анда Идегәй турындагы эпосны популярлаштыру һәм Алтын Урда тарихын яктыртуда «милли характердагы» хаталар күрсәтелә, соңыннан Мәскәүдә СССР ФАнең Тарих һәм филос. бүлеге сессиясендә (к. *СССР Фәннәр академиясе Фәнни сессиясе*, 1946 ның 25–26 апр.) татарларның болгарлардан килеп чыгуы турындагы теория көчләп тагыла. Шушы вакыттан Т.һ.т.х.т.ө.г. Алтын Урда тарихыннан аерыла, анда тарихи тикшеренүләрнең өстенлекле темалары билгеләнә, аларга идарә итүче коммунистик режимнан социаль заказ килә. Болар барысы да тарихи хезмәтләр басылуның кимүенә, Т.һ.т.х.т.ө.г.ннән тарихи вакыйгаларда катнашучылардан күбесенең исеме нигезсез юкка чыгуга китерә.

1950 еллар ахырыннан Т.һ.т.х.т.ө.г.үсешендә илдәге сәяси режим либеральләшү б-н бәйле яңа этап башлана. Тикшеренүчеләр элек тыелган темаларны өйрәнү һәм ябык архив материалларын эштә куллану мөмкинлеге алалар. Аерым мәсьәләләр буенча фәнни кадрлар специальләштерелә һәм билгеләнә. Т.һ.т.х.т.ө.г.ндә Татарстан һәм татар халкы тарихы буенча «Татарстан АССР тарихы» («История Татарской АССР», т. 1–2, 1955–60), «Урта Идел һәм Урал буе татарлары» («Татары Среднего Поволжья и Приуралья», 1967) фундаменталь хезмәтләре зур вакыйга була. Документаль материалларны ачуга һәм нәшер итүгә җитди игътибар бирелә башлый. Бөек Ватан сугышына, халык хуҗалыгын индустрияләштерүгә, а.х.н күмәкләштерүгә, крәстияннәр хәрәкәтенә, В.И.Ленинга, ТАССРда милли дәүләт төзелешенә, ТАССР барлыкка килүгә, сәнәгать һәм эшчеләр классына һ.б. багышланган күпсанлы документлар һәм материаллар җыентыгы нәшер ителә (к. *Чыганакларны өйрәнү гыйлеме*). 1960–80 елларда ш.у. Т.һ.т.х. т.ө.г.нең аерым мөһим мәсьәләләре тикшерелә. Татар халкының килеп чыгышы, аның этник тарихы Ф.Т.*Вәлиев*, Н.И.Воробьёв, Р.Г.*Мөхәммәдова*, А.Х.Халиков һ.б.ның хезмәтләрендә чагыла. Н.Ф.*Калинин*, Ш.Ф.*Мөхәммәдьяров*, А.П.Смирнов, М.Г.*Госманов*, Р.Г.*Фәхретдинов*, А.Х.*Халиков* һ.б.ның хезмәтләре Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы тарихына багышлана. Рус дәүләтенә кушканнан соң төбәк үсеше, 1860–80 еллардагы реформалар, крепостной хокук бетерелү, иҗтимагый һәм революцион хәрәкәтләр, Татарстанда капитализм үсеше, татар буржуазиясенең яралуы, җәдитчелек, 1905–07 елгы рев-ция, татар конфессиональ мәгарифе тарихы Я.Г.*Абдуллин*, С.Х.*Алишев*, Г.Н.*Вульфсон*, Р.А.*Гарәфетдинов*, И.П.*Ермолаев*, А.Х.Мәхмутова, С.М.*Михайлова*, Р.И.*Нәфыйгов*, Е.Д.*Румянцев*, Ю.И.*Смыков*, В.Н.*Смирнова*, Х.Х.*Хәсәнов*, Р.С.*Цейтлин*, Е.И.Чернышёв һ.б. тарафыннан өйрәнелә. Ленин тематикасы М.К.*Мөхәррәмов*, Р.И.Нәфыйгов, М.А.Сәйдәшева, Х.Х.Хәсәнов, Я.Ш.*Шәрәпов* һ.б. хезмәтләрендә тикшерелә. Февр. һәм Окт. рев-цияләре тарихы, революцион, милли-демократик, крәстияннәр һәм солдатлар хәрәкәте Р.К.*Вәлиев*, И.М.*Ионенко*, И.Р.*Таһиров* хезмәтләрендә ачыла. Гражданнар сугышы чоры, «хәрби коммунизм» сәясәте И.Г.Гыйззәтуллин, А.Л.*Литвин*, М.К.Мөхәррәмов, Я.Ш.Шәрәпов һ.б. хезмәтләрендә чагыла. ТАССР барлыкка килү тарихы һәм шуннан соңгы милли дәүләт төзелеше Р.К.Вәлиев, И.М.*Климов*, М.К.Мөхәррәмов, Р.И.Нәфыйгов, И.Р.Таһиров, Р.Г.*Хәйретдинов*, Ш.Ш.Хафизов һ.б.ның хезмәтләрендә карала. Индустрияләштерү, күмәкләштерү һәм мәдәни тө-

зелеш нәтиҗәләре У.Б.*Билалов*, З.Г.Гарипова, Г.Л.*Горник*, А.М.*Залялов*, К.А.Нәҗипова, М.З.*Тутаев*, В.Б.*Токарев*, Е.И.*Устюжанин* һ.б.ның хезмәтләрендә гомумиләштерелә. Бөек Ватан сугышы чоры, Татарстанда туганнарның хәрби батырлыклары, тыл тормышы А.К.Айнетдинов, Җ.И.*Гыйльманов*, И.М.*Ионенко*, В.А.Попов, Г.С.*Сабирҗанов*, Л.И.Ханин һ.б.ның хезмәтләрендә, «Советлар Союзы Геройлары — безнең якташлар» («Герои Советского Союза — наши земляки», кн. 1–3, 1982–85), «Дан ордены тулы кавалерлары — безнең якташлар» («Полные кавалеры ордена Славы — наши земляки», 1987) китапларында карала. 1960–80 елларда индустрия үсеше, нефть сәнәгате, эшчеләр сыйныфы тарихы Р.К.*Беляев*, С.Л.*Князев*, Т.И.Славко, Ф.Ә.*Табиев*, В.Б.Токарев, М.Г.Шәмсиев һ.б.ның хезмәтләрендә, «Татарстанның эшчеләр сыйныфы (1861–1980 еллар)» («Рабочий класс Татарии (1861–1980 гг.)», 1981) китабында чагыла. 1950–80 елларда Казан тарихына багышланган хезмәтләр барлыкка килә: «Казан. Тарихи очерк» («Казань. Исторический очерк», Калинин Н.Ф., 1955), «Борынгы шәһәрнең яшьлеге» («Молодость древнего города», 1978), «Казан тарихы» («История Казани». кн. 1–2, 1988–91) җыентыклары. Аерым тарихи чорлар һәм мәсьәләләр тигез өйрәнелми. Тарихи күренешләрне бәяләүләрнең күбесе вакыт сынавын уза алмый, күп кенә тикшеренүләрдә Татарстан һәм татар халкы үсешендәге җитди кыенлыклар күрсәтелми.

Татарстан һәм татар халкы мәдәнияте «Татарстанда мәдәният төзелеше (1917–1941 еллар)» («Культурное строительство в Татарии (1917–1941гг.)», 1971), «Татарстанда мәдәният төзелеше (1941–1970 еллар)» («Культурное строительство в Татарии (1941–1970 гг.)», 1976), «Татарстанда мәдәният революциясе (1917–1985 еллар)» («Культурная революция в Татарии (1917–1985 гг.)», 1986) җыентыкларында, Д.К.Вәлиеваның «Идел буе болгарлары сәнгате» («Искусство волжских булгар», 1982), Ю.А.Благовның «Казан Яшь тамашачылар театры: Тарихи очерк» («Казанский Театр юного зрителя: Очерк истории», 1986), Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманованың «Татарстанның гамәли бизәлеш сәнгате (1920–1990 еллар)» («Декоративное искусство Татарстана (1920–1990 годы)», 1995), Р.А.Исхакова-Вамбаның «Татар халык музыка иҗаты» («Татарское народное музыкальное творчество», 1997) һ.б. китапларда чагылыш таба. Сынлы сәнгать, архит-ра, музыка, театр тарихы буенча түбәндәге белешмә-басмалар: «Татарстан Республикасы: тарихи һәм мәдәни ядкәрләр» («Республика Татарстан: памятники истории и культуры», 1993), «Татарстан Республикасы: Татар халкы тарихы һәм мәдәнияте ядкәрләре (XVIII йөз ахыры — XX йөз башы)» («Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII – начало XX вв.)», 1995); китаплар: «Татарстан рәссамнары» («Художники Татарии», Елькович Л.Я., Л., 1965), «Совет Татарстаны рәссамнары» («Художники Советской Татарии», Червонная С.М., 1975), «Совет Татарстаны сәнгате: нәкыш сәнгате, скульптура, графика» («Искусство Советской Татарии: живопись, скульптура, графика», М., 1978), «Татарстанның музыкаль культурасы эшлеклеләре» («Деятели музыкальной культуры Татарии», Кантор Г.М., 1987), «Г.Камал исемендәге театр артистлары» («Артисты театра им.Г.Камала», Илялова И.И., 1996) һәм аерым рәссамнар, композиторлар, театр эшлеклеләре һ.б. иҗатына багышланган күп кенә хезмәтләр: «Салих Сәйдәшев: Материаллар һәм истәлекләр» («Салих Сайдашев: Материалы и воспоминания», 1970), «Бакый Урманче: Альбом» («Баки Урманче: Альбом», 1982), «Харис Якупов» (1983), «Хәлил Әбҗәлилов» («Халил Абжалилов», 1984), «Гөлсем Болгарская» (1985), «Ф.Яруллин һәм татар балеты» («Ф.Яруллин и татарский балет», 1986), «Хөсәен Уразиков» («Хусаин Уразиков», 1986), «Мансур Мозаффаров» («Мансур Музафаров», 1993), «Марсель Сәлимҗанов» («Марсель Салимжанов», 1993), «Газиз Әлмөхәммәтов һәм Солтан Габәши Казанда» («Газиз Альмухамедов и Султан Габяши в Казани», 1995), «Константин Васильев дуслары күзлегеннән» («Константин Васильев глазами друзей», 1995) нәшер ителә.

Фән үсеше тарихы «50 еллык эзләнүләр һәм ачышлар» («50 лет поисков и открытий», 1989), «Эзләнүләр һәм ачышлар: гуманитар белем үсешендә фәнни-тикшеренү институтларының роле» («Поиски и открытия: роль научно-исследовательских институтов в становлении гуманитарного знания», 2015), «Казан авиация институты» («Казанский авиационный институт», 1992), «Тарих белән яшәргә: Казан университетының тарих факультетына 60 ел» («Жить историей: 60 лет историческому факультету Казанского университета», 1999), «Борылыш унъеллыгы. Казан дәүләт технология университеты (1991–2000). Тарихи очерк» («Переломное десятилетие. Казанский государственный технологический университет (1991–2000). Исторический очерк», 2000), «Казан университеты тарихы (1804–2004)» («История Казанского университета (1804– 2004)», 2004), «Казан университеты тарихы очерклары» («Очерки истории Казанского университета», 2002) җыентыкларында, ш.у. А.Е.Арбузовның «Казан химия мәктәбе» («Казанская химическая школа», 1971) китабында анализлана. Татарстанның рухи һәм матди мәдәнияте сәнгатькәрләр (к. *Сәнгать гыйлеме*), әдәбиятчылар (к. *Әдәбият белеме*), музыка белгечләре (к. *Музыкаль культура*), театр белгечләре (к. *Театр сәнгате гыйлеме*), фольклорчылар (к. *Фольклористика*), археологлар (к. *Археология*), этнографлар (к. *Этнография*), философлар һ.б. тарафыннан өйрәнелә.

1990 еллардан тарихка марксистик-ленинчыл карашны яңадан күздән кичерүгә бәйле рәвештә Т.һ.т.х.т.ө.г. үсешендә яңа этап башлана. Россия җәмгыятенең сәяси-икътисади тормышын үзгәртеп кору һәм тарихи әдәбиятның коммунистик идеологемалардан арынуы барышында Татарстан тарихындагы «ак тапларны» бетерү, онытылган исемнәрне кире кайтару, процессларга һәм вакыйгаларга объектив бәя бирү буенча эш башлана. Документаль материалларны нәшер итүгә җитди игътибар бирелә. Татар халкы тарихына, сәяси репрессия корбаннарына (ш.и. М.Солтангалиевкә, Е.Г.Гинзбургка) һәм башка аспектларга багышланган документаль чыганаклар сериясе бастырыла, ул Татарстан һәм татар халкының социаль-икътисади һәм этномәдәни тарихына яңача караш өчен нигез булып тора. Татар халкы тарихын өйрәнү тикшеренүләрдә мөһим юнәлешкә әверелә. Татар халкы тарихының, аеруча урта гасырлар дәверенең (К.А.Әбләзов, А.Ә.Борһанов, Р.М.Вәлиев, Г.М.*Дәүләтшин*, И.Л.Измайлов, Д.М.*Исхаков*, А.П.Казаков, Ф.Г.Кәлимуллина, Ә.Г.*Мөхәммәдиев,* А.Г.Ситдыйков, И.Р.Таһиров, Р.Г.Фәхретдинов, Ф.Ш.Хуҗин һ.б. хезмәтләрендә) күп кенә аспектлары билгеләнә һәм яңача аңлатыла. М.Г.Госманов, Р.Г.Фәхретдинов, И.Л.Измайлов, Д.М.Исхаков хезмәтләрендә Алтын Урда тарихын һәм аның татар халкының этник һәм сәяси тормышында урынын яктыртуга зур игътибар бирелә. ТРның 20 йөз — 21 йөз башындагы иҗтимагый-сәяси, милли-мәдәни, социаль-икътисади һәм иҗтимагый-хокукый тарихын өйрәнүдә яңача фикерләүләр юл ала (Р.К.Вәлиев, И.А.Гыйләҗев, Ә.Г.Галләмова, С.И.Никонова, Ф.А.Рәшитов, Б.Ф.Солтанбәков, И.Р.Таһиров, Э.Р.Таһиров, Р.В.Шәйдуллин һ.б.), исламны өйрәнүдә яңа методологик юллар билгеләнә (Р.М.*Вәлиев*, Д.М.Исхаков, Р.М.*Мөхәммәтшин*, Р.Ә.Нәбиев һ.б.), сәяси репрессияләр һәм аларның корбаннарының язмышы яңача яктыртыла (Р.К.Вәлиев, А.А.Иванов, А.Л.Литвин, С.Ю.*Малышева*, Б.Ф.*Солтанбәков*, И.Р.Таһиров һ.б.), рус һәм татар халкы арасындагы үзара мөнәсәбәтләр характеры (С.Х.Алишев, Г.С.Сабирҗанов, Г.Г.Хафизов һ.б.), массакүләм мәгълүмат чаралары (А.К.Айнетдинов, Р.А.Айнетдинов, Р.Г.Әмирханов, З.З.Гыйләҗев, Р.Ф.Мәрданов, Р.М.Нуруллина һ.б.), конфессиональ сәясәт һәм мәгариф (Е.А.*Вишленкова*, И.К.Заһидуллин, Ф.Г.Ислаев, А.Х.Мәхмүтова, Р.М.Мөхәммәтшин, Р.Ә.Нәбиев һ.б.), иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләр (Л.М.Айнетдинова, Р.К.Вәлиев, А.А.*Литвин*, А.Ю.*Хәбетдинов* һ.б.), аграр тарих (Д.В.Давыдов, Ф.Г.Зәйнуллина, И.К.Заһидуллин, Н.А.Фёдорова, Р.Р.Хәйретдинов, Р.В.*Шәйдуллин* һ.б.), мөселман парламентаризмын (И.Р.Таһиров, Д.М.Госманова, Р.А.Циунчук һ.б.) өйрәнү буенча тикшеренүләр дәвам иттерелә, татар китабы (Ә.Г.*Кәримуллин*), төрки-татарларның традицион бәйрәмнәре һәм гореф-гадәтләре (Р.К.Уразманова), татар-башкорт көрәше (Д.Р.*Шәрәфетдинов*) һ.б. тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертелә. Бу чорда төбәктә Россия хөкүмәте этноконфессиональ сәясәтенең төрле аспектларын (И.К.Заһидуллин, Ф.Г.Ислаев, О.Н.*Коршунова*, А.И.Ногманов һ.б.), Бөек Ватан сугышы тарихын (И.А.*Гыйләҗев*, А.А.*Иванов*, А.Ш.Кәбирова, Е.Г.Кривоножкина, Р.Р.Сәләхиев, М.В.Черепанов һ.б.) яктырткан яңа хезмәт-

ләр барлыкка килә. Тарихи тикшеренүләрдә хәзерге Татарстанда баручы процессларны яктыртуга зур игътибар бирелә (Д.К.*Сабирова*, Ф.М.*Солтанов*, И.Р.Таһиров, Э.Р.*Таһиров* һ.б.). Татар энциклопедистикасы мәсьәләләре Татарстанда яңа историография юнәлеше буларак, башлыча, ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү ин-ты галимнәре тарафыннан яктыртыла (Л.М.Айнетдинова, Г.С.Сабирҗанов, Р.В.Шәйдуллин, А.Г.Ярулина һ.б.). Татарстан авыллары, шәһәрләре тарихы галимнәрнең хезмәтләрендә (Р.Ф.Галләмов, Р.Ф.Мәрданов, А.И.Ногманов, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хәйретдинов, Р.В.Шәйдуллин һ.б.) һәм «Лаеш төбәге тарихы» («История Лаишевского края», 1997), «Татарстан Республикасының торак пунктлары. Кыскача белешмәлек» («Населённые пункты Республики Татарстан. Краткий справочник», 1997), «Сарман районы энциклопедиясе» (Чаллы, 2000), «Азнакай: Китап-альбом» («Азнакай: Книга-альбом», 2001), «Иң биек урында: Бөгелмә шәһәренә — 220 ел» («На высоком месте: Городу Бугульма — 220 лет», Бугульма, 2002), «Әлмәт» («Альметьевск», 2003) һ.б. китапларда чагылыш таба.

Татарстан һәм татар халкы тарихы буенча гомумиләштерелгән хезмәтләрнең басылып чыгуы зур вакыйга була: «Татарлар» («Татары», М., 2001), «Иң борынгы заманнардан татарлар тарихы» («История татар с древнейших времён», т. 1–7, 2002–14), «Урта Идел буенда ислам һәм мөселман культурасы: тарих һәм хәзерге заман» («Ислам и мусульманская культура в Среднем Поволжье: история и современность», 2002); И.Р.Таһировның «Татарстан һәм татар халкы тарихыннан очерклар (XX йөз)» («Очерки по истории Татарстана и татарского народа (XX век)», 1999) һәм «Татар халкы һәм Татарстанның милли дәүләтчелеге тарихы» («История национальной государственности татарского народа и Татарстана», 2000), Ф.Г.Рәшитовның «Татар халкы тарихы: Иң борынгы заманнардан безнең көннәргә кадәр» («История татарского народа: С древнейших времён до наших дней», Саратов, 2001), Р.Х.Теляшовның «Санкт-Петербургта татар җәмгыяте. Шәһәрнең 300 еллыгына» («Татарская община Санкт-Петербурга. К 300-летию города», СПб., 2004), К.Ә.Әбләзовның 2 томлык «Татарларның тарихи язмышы» («Историческая судьба татар» в 2-х т., Саратов, 2012).

Чит илләрдәге Т.һ.т.х.т.ө.г.ндә 20 йөз башына кадәр Татарстан һәм татар халкы тарихы буенча тулы булмаган мәгълүматлар китерелә, алар күбесенчә каршылыклы фикерләргә нигезләнә. 1940–50 елларда Татарстан тарихы б-н кызыксыну җанлана. СССР һәм милли респ-калар тарихы буенча махсус фәнни хезмәтләр барлыкка килү, нигездә, идеологик шартлар б-н бәйле була, аларда ике системаның каршылыклы йогынтысы ачыктан-ачык сизелә. Шул сәбәпле чит илләрдәге Т.һ.т.х.т.ө.г.ндә төп игътибар СССРдагы милли сәясәткә, милли-терр., иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләр һәм аларның җитәкчеләренә юнәлтелә.

Көнчыгышны өйрәнүче күренекле немец галиме Г. фон *Менде* үзенең хезмәтен («Der nationale Kampf der Ruslandturken: Ein Beitrag zur nationalen in der Sowjetunion», B., 1936) төркиләрнең (ш.и. татарларның) Окт. рев-циясенә кадәрге милли хәрәкәтен һәм аның лидерларының ролен тәфсилле тасвирлауга багышлый. Шул ук мәсьәләләр аның ватандашы Б.Шпулер хезмәтләрендә дә («Idel-Ural», B., 1942; «Die Wolga Tataren und Baschkiren unter russichen Herrschaft», «Die Welt des Islam» җыентыгында басыла, B., 1949) күтәрелә. Р.Пайпс («The Formation of the Soviet Union», Camb., 1954) Совет дәүләтенең Татар-башкорт респ-касы төзүгә мөнәсәбәтен һәм аннан баш тарту сәбәпләрен (башлыча, М.Вахитовның үтерелүенә бәйләп) анализлый. С.Зеньковский «Россиядә пантюркизм һәм ислам» («Пантюркизм и ислам в России», «Pan-Turkism and Islam in Russia», Camb., 1960) хезмәтендә 19 йөздә — 20 йөз башында Россиядә мөселманнарның иҗтимагый-сәяси хәрәкәтенә тулы характеристика бирә. Аның фикеренчә, татарлар арасында иң киң таралган идеяләр либерализм һәм милли-мәдәни автономия булган. Ул Россия үзәгендә «Идел-Урал» штаты һәм аерым мөселман терр. мохтарияте төзергә омтылу төптән ялгыш фикер булган дип саный. А.Беннигсен һәм Ш.Лемерсье-Келькеже үз хезмәтләрендә («Les mouvements nationaux chez les Musulmans de Russie: «Le Sultangalievisme» au Tatarstan», P., 1960; «La presse et le mouvement national ches les Musulmans de Russie avant 1920», P., 1964) татар җәмгыятенең иҗтимагый-сәяси тормышын, аның рухи һәм интеллектуаль ресурсларын, 19 йөз ахырында — 20 йөз башында мөселман реформаторлыгы характерын һәм үзенчәлекләрен анализлыйлар. Алар М.Солтангалиевнең тормышы һәм эшчәнлеге мисалында Совет дәүләте һәм Окт. рев-циясеннән соң да милли идеяне якларга тырышкан татар интеллигенциясе вәкилләре арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне күрсәтәләр. Француз галиме Ф.Жоржонның «Төрки милләтчелек барлыкка килү турында: Йосыф Акчура» («Aux origines du nationalisme Turk: Yusuf Akchura (1876–1935)», P., 1980) хезмәтендә Россиядә иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләрнең формалашуы, пантюркизм барлыкка килү сәбәпләре һәм нигезләре өйрәнелә. Америка тарихчысы Э.Лаззерини тикшеренүләре җәдитчелек мәсьәләсе, аның барлыкка килүе һәм үсешендә И.Гаспринскийның ролен өйрәнүгә багышлана. Ә.-А.Рорлихның «Милли тотрыклылык күзлегеннән Идел буе татарлары» («The Volga Tatars. A Profile in National Resilience», Stanford, 1986) китабында чит илләрдәге Т.һ.т.х.т.ө.г.ндә беренчеләрдән булып татарларның үсеш процессы этнос формалашудан башлап хәзерге вакытка кадәр өйрәнелә. Башка фундаменталь тикшеренүләр арасында япон тарихчысы Н.Ямаучинын «Солтангалиев хыялы» (Токио, 1986; япон телендә) хезмәте аерым урын били. Б.*Ишболдинның* («Essays on Tatars History», New Dehli, 1963) һәм Я.Пеленскийның («Russia and Kazan. Conquest and Imperial ideology (1438–1560)», P., 1974) тикшеренүләре, башлыча, татарларның урта гасырлар тарихына һәм татар һәм рус халыкларының үзара мөнәсәбәтләренә багышлана.

1990 елларда чит илләрдәге Т.һ.т.х.т.ө.г.ндә, туган илебездәге кебек үк, шактый үзгәрешләр була: тарихи тикшеренүләрнең чыганаклар базасы, фәнни мәсьәләләр даирәсе киңәя, күп кенә хезмәтләр элеккеге идеологемалардан сизелерлек дәрәҗәдә арына. Алтын Урдадан башлап, татарлар тарихының барлык чорлары да диярлек чит илләрдәге Т.һ.т.х.т.ө.г.нең игътибар үзәгендә була. Америка тикшеренүчесе Д. де Визе Алтын Урдада исламлашу процессын һәм исламның рәсми дингә әверелүен анализлый («Islamisation and native religion in the Golden Horde: Baba Tukles and conversion to Islam in historical and epic tradition», Pensylvania, 1994). Немец галиме М.Кемпер «1789–1889 елларда Татарстанда һәм Башкортстанда суфилар һәм галимнәр: Рус хакимияте астында ислам дискурсы» («Sufis und Gelehrte in Tatarien und Baschkirien 1789–1889: der Islamische Diskurs unter russicher Herrschaft», Берлин, 1998) китабында татар иҗтимагый фикеренең төп агымнарын, аларның танылган вәкилләре (Г.Курсави, Г.Утыз Имәни һ.б.) арасындагы дини бәхәсләр характерын яктырта. Америка тарихчысы А.Франк тикшеренүләренең темасы — татарларның милли үзаңы формалашу процессы («Islamic Historiography and «Bulgar» Identity among the Tatars and Bashkirs of Russia», Leiden, 1998). 19 йөздә — 20 йөз башында Россия дәүләтендәге империячел сәясәтнең татарларга мөнәсәбәте П.Уэрт («At the Margins of Orthodoxy: Mission Governance and Confessional Politics in Russia Volga-Kama Region, 1827–1905», L., 2001), Р.Джераси («Window on the East: National and Imperial Identities in Late Tsarist Russia», L., 2001), С.Гёкгюз, Х.Комацу, К.Нисияма, Н.Наганава, Й.Окумура һ.б. хезмәтләрендә карала. Француз тикшеренүчеләре С.Дюдуаньон, Т.Заркон, Төркия галимнәре А.Канлыдере, И.*Мараш*, И.*Төрекоглы*, шу. Н.*Дәүләт*, Г.*Айда*, Америка галимнәре Ю.*Шамил углы*, А.Халид, Х.Альгар үз хезмәтләрендә татар җәмгыятен модернизацияләүнең төрле аспектларын һәм шул җәмгыятьнең традицион нигезләре сакланыны анализлыйлар, күренекле татар эшлеклеләренең (Р.Ибраһимов, С.Максуди, Р.Фәхретдин һ.б.) иҗтимагый фикер үсешендәге ролен күрсәтәләр. Ш.у.к. *Тарих, Татар халкын өйрәнү гыйлеме (Татарика), Тюркология*.

*Әд.:* Рәхим Г. Материалы для библиографии по татароведению (1918–1929). К., 1930; Мухарямов М.К., Гильманов З.И. Развитие исторической науки в ИЯЛИ КФАН СССР (1946–1973) // Татария в прошлом и настоящем. К., 1975; шулар ук. Основные итоги изучения на современном этапе истории татарского народа // Исследования по историографии Татарии. К., 1978; Кто есть кто в науке об искусстве (Республика Татарстан): Справ. К., 1998; История Татарской АССР (с древнейших времён до наших дней): Указ. советской литературы 1917–1959. К., 1960; Исто-

рия Татарской АССР (с древнейших времён до наших дней): Указ. литературы 1967–1975. К., 1986.

*И.Р.Вәлиуллин, Р.М.Мөхәммәтшин, Р.В.Шәйдуллин.*

**ТАТАРСТА́Н ЧИМА́Л КАЛДЫКЛАРЫ́Н ҖЫЮ́ ҺӘМ ЭШКӘРТҮ́ КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́ КООПЕРА́ЦИЯЛӘРЕ БЕРЛЕГЕ́** (Татутильпромсоюз), 1932 елның августында Казанда оештырыла. Чимал калдыкларын җыю һәм эшкәртү б-н шөгыльләнүче артельләрне берләштерә, аларның хуҗалык һәм финанс эшчәнлегенә җитәкчелек итә. *Татарстан кәсепчелек кооперативлары советына* буйсына. 1934 нең июнендә эшчәнлеге туктатыла, аңа кергән артельләр Татарстанның күптөрле кәсепчеләр берлеге карамагына тапшырыла.

**«ТАТАРСТА́Н ЭСТАФЕ́ТАСЫ»**, көзге арыш сорты. 1995 елда «Татарстан кыры» ФҖБдә М.Л.*Пономарёва*, С.Н.*Пономарёв*, В.Д.Кобылянский, О.В.Солодухина тарафыннан чыгарыла. Уртача соң өлгерешле сорт, вегетация чоры 321–340 көн. Үсемлекнең биеклеге 110–125 *см*. Башагы призмасыман, озын, көпшәк, сары төстә, кылчыклары озын. Бөртеге эре (1000 данәнең авырлыгы 32–38 *г*), югары натуралы (695–710 *г/л*), лизины һәм аксымы күп. Икмәк пешерү сыйфатлары бик яхшы, сөрлегүгә, салкынга чыдам, өнчыл чык, көрән гөмбә, кар күгәреге авыруларына бирешми. Иртә үсүе һәм яхшы куаклануы сәбәпле, «Т.э.» сорты яшел азык өчен үстерелә. 1998 дә Урта Идел һәм Идел-Вятка регионнарында чәчәргә рөхсәт ителгән сортлар дәүләт реестрына кертелгән.

*Әд.:* Каталог научно-технической продукции. К., 2005.

**«ТАТАРСТА́Н – ЯҢА ГАСЫ́Р»**, респ-кадагы иҗтимагый хәрәкәт. Татарстан җитәкчелеге инициативасы б-н респ-каның мөстәкыйльлеген киңәйтү яклы сәяси көчләрне бергә туплап ныгыту максатыннан оештырыла. 1999–2004 елларда иң югары идарә органы — съезд. Барлыгы 6 съезд уздырыла (Казан) (оештыру съезды — 1999 елның 3 июле, 6 нчысы — 2004 нең 3 июле). 2005 тән иң югары идарә органы булып конференция исәпләнә. Казанда 2 конференция уздырыла: 2005 нең 24 сентябре, 2009 ның 2 июле. Конференцияләрдә (съездларда) сәяси совет һәм контроль комиссиясе сайлана. Сәяси совет президиум, рәис һәм аның урынбасарларын сайлый. 1999 елдан «Т. – Я.г.» сәяси советы рәисе — Ф.Х.Мөхәммәтшин, совет әгъзалары — М.М.Абдуллин, Р.И.Әдһәмов, Ю.П.Алаев, М.Г.Галиев, И.Ш.Мостюков, Ю.И.Петрушин, Р.А.Ратникова, А.Я.Славутский, Ш.Ф.Тәхәветдинов, Р.С.Хәкимов һ.б. «Т.-Я.г.»га Казан, Чаллы шәһәрләрендә һәм респ-каның 43 муниципаль р-нында эшләүче 45 терр. бүлек керә. Терр. бүлекнең иң югары идарә органы булып конференция исәпләнә, ул совет һәм контроль комиссиясен сайлый. Совет әгъзалары арасыннан советның рәисе һәм урынбасарлары сайлана. «Т. – Я.г.» ның терр. бүлеге составында (муниципаль берәмлекләр кысаларында) җирле бүлекләр оештырыла ала, аларның югары идарә органы булып катнашучылар җыелышы тора.

«Т. -Я.г.» Уставы күмәк һәм шәхси әгъзалык мөмкинлекләрен күздә тота. Күмәк катнашучылар саны: 1999 да — 21, 2004 тә — 10, 2009 да — 13. «Т. – Я.г.» ның беренче күмәк катнашучылары арасында – «Бердәмлек һәм прогресс» партиясе (рәистәшләре А.А.Колесник, Р.С.Хәкимов, А.И.Щеповских), Татарстан Республика партиясе (лидеры М.Г.Сабиров), «Татарстан яңарышы өчен» Респ-ка иҗтимагый-сәяси оешмасы (рәисе М.П.Девятаев), ш.у. «Россия — безнең йортыбыз» (А.М.Габетдинова), «Ватан» (Ф.И.Гайнуллина), «Россия төбәкләре» (Н.К.Хөснетдинов), «Тигез хокуклылык һәм гаделлек өчен» (С.А.Брусов) гомумроссия хәрәкәтләре һәм оешмаларының төбәк бүлекләре. 2003 кә әлеге барлык оешмаларның эшчәнлеге туктала. 2009 ның июленә «Т. – Я.г.» тарафдарларының гомуми саны 110 меңләп кеше тәшкил итә. «Т. – Я.г.» ның күмәк катнашучылары: «Россиянең инженерлык тәрәкъкыяте» гомумроссия хәрәкәтенең Казан бүлекчәсе (Р.И.Әдһәмов), «Россия халыклары берлеге» Бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең төбәк бүлеге (М.А.Гаделшин), Татарстан халыклары ассамблеясе (Ф.Х.Мөхәммәтшин), ТР Журналистлар берлеге (Р.А.Ратникова), ТР Театр эшлеклеләре берлеге (Р.А.Таҗетдинов), ТР Эшмәкәр хатын-кызлар берлеге (Р.К.Ким), «Татарстан геройлары» иҗтимагый оешмасы (И.Ш.Мостюков), ТР Яшьләр оешмалары советы (И.И.Гыйльметдинов), ТР «Ватан» берләшмәсе» иҗтимагый яшьләр оешмасы (җитәкчесе А.Ю.Коноплёв) һ.б. 2000 нең мартында «Т. – Я.г.»ның Яшьләр берләшмәсе (рәисе Ә.А.Кармиев), 2000 дә «Татарстан — Яңа гасыр яшьлеге» балалар оешмасы (рәисе Н.О.Үмәров) барлыкка килә.

Хәрәкәтнең идеологик доктринасы аның сәяси платформасында (оештыру съездында кабул ителә) һәм программасында (3 нче съездда кабул ителә) чагылыш таба. Платформада хәрәкәтнең Россиядә демократик кыйммәтләр, гражданлык җәмгыяте ин-тлары һәм федерализмны саклау һәм алга таба үстерүгә йөз тотуы хакында әйтелә; федераль үзәкнең нәкъ менә федералистик принципларны тормышка ашырудагы эзлексезлеге, Россия төбәкләрен алга таба үстерү мәсьәләләренә җитәрлек игътибар булмауның 1990 еллар ахырындагы социаль-икътисади һәм сәяси кризисның авыр нәтиҗәләренә китерүе төп сәбәп икәнлеге раслана, шуннан чыгып, Россия төбәкләрендә, ш.и. Татарстанда да мөстәкыйльлекне арттыру мөһимлеге турында нәтиҗә ясала. «Т. – Я.г.» программасында үзәктән читләшү векторы көчлерәк чагыла. Хакимиятне ныгытуга, РФ субъектларының сәяси һәм икътисади мөстәкыйльлекләрен кыскартуга юнәлдерелгән федераль сәясәткә җавап итеп, программада әлеге сәясәтнең Россия дәүләтенең РФ Конституциясе б-н игълан ителгән федератив характерын шик астына куюы турында белдерелә. Татарстан дәүләт статусының хокукый нигезе респ-каның дәүләт суверенлыгы турындагы Декларация нигезләмәләре (1990), ТРның статусы турында респ-ка референдумы нәтиҗәләре (1992), ТР Конституциясе нормалары (1992), РФ һәм ТР арасындагы Шартнамә (1994) нигезләмәләре б-н билгеләнүе ассызыклана. «Т. – Я.г.» программасында респ-каны модернизацияләүгә булышырга һәм аны көндәшлеккә дәгъва итүче төбәккә әйләндерергә, респ-кага яңалык кертүгә ярдәм итәргә тиешле «Татарстанның сәяси централизм доктринасы»н яклау турында игълан ителә. «Т. – Я.г.» ның иң мөһим иҗтимагый-сәяси бурычлары: сүз иреген, массакүләм мәгълүмат чараларының бәйсезлеге, коррупциягә каршы көрәш, Россия федерализмын асимметрия принциплары нигезендә үстерү, җирле үзидарәне үстерү. Икътисад өлкәсендә хуҗалык итүче субъектларга, милек төренә карамастан, бертигез шартлар гарантияләү; бериш продукция җитештерү өлкәсендә дәүләт тарафыннан конкурентлык мохитен яклау, табигый монополияләргә күзәтчелек итү, дәүләт заказы системасын камилләштерү; респ-каның икътисади куркынычсызлыгын тәэмин итүче тармакларда дәүләт күзәтчелеген саклап калу; салым күләмен киметү; респ-каның инвестицион җәлеп итүчәнлеген ныгыту; базар таләпләренә җайлаштырылган барлык тармакларда югары технологияләрне үстерүгә ориентлашу; кече бизнесны яклау; идарә аппаратын оптимальләштерү. Программа социаль сферада хәрәкәтнең дәүләт патернализмы принципларына нигезләнүен игълан итә.

«Т. – Я.г.»ның сәяси активлыгы һәм йогынтысы аеруча көчле чор 1999–2001 гә туры килә. Хәрәкәт «хакимият партиясе» ролендә була. «Т. – Я.г.» 1999–2000 еллар сайлау кампанияләре барышында аерым активлык күрсәтә. 1999 елгы РФ Дәүләт Думасына сайлауларда «Т. – Я.г.»ның башкарма ком-ты нигезендә «Ватан — бөтен Россия» блогының төбәк сайлау штабы формалаштырыла, аны оештыру инициаторларының берсе — М.Ш.Шәймиев; сайлау нәтиҗәләре буенча «Т. – Я.г.»ның 3 вәкиле депутат була (Ф.И.Гайнуллина, М.Р.Рокицкий, Н.К.Хөснетдинов). 1999 да ТР Дәүләт Советына сайлауларда һәм 2000 дәге өстәмә сайлауларда «Т. – Я.г.»ның кандидатлар күрсәтүгә хокукы булмый, ләкин кандидатларның кайберләрен яклау турында хәбәр ителә; тавыш бирү нәтиҗәләре буенча «Т. – Я.г.» сәяси советының 6 әгъзасы (Ф.Х.Мөхәммәтшин, Е.Б.Богачёв, М.Г.Галиев, Ш.Ф.Тәхәветдинов, Р.Р.Туфитуллова, А.М.Пахомов), ш.у. хәрәкәттә катнашучы 13 кеше (Р.И.Вәлиев, Р.Х.Зарипов, И.А.Ларочкина, В.Н.Липужина, В.П.Логинов һ.б.) депутат була. 1999–2000 елларда җирле советларга сайлауларда һәм өстәмә сайлауларда «Т. – Я.г.» ярдәме б-н күп кенә кандидатлар күрсәтелә. Нәтиҗәдә, 2000 нең июленә федераль, респ-ка һәм җирле сайлауларда «Т. – Я.г.» тарафыннан яклангaн 721 кандидатның 649 ы депутат булып сайлана. 2000 дә сәяси фикер каршылыгы нәтиҗәсендә «Т. – Я.г.»дан Татарстан Респ-ка партиясе аерылып чыга (соңыннан оппозициягә күчә). Хәрәкәт 2000 дә һәм 2004 тә

РФ Президентын сайлауларда В.В.Путин кандидатурасын, 2001 дә ТР Президентын сайлауларда М.Ш.Шәймиев кандидатурасын яклый. ТРның 2 нче чакырылыш (1999–2004) Дәүләт Советы составында «Т. – Я.г.» ның координаторлары М.Г.Галиев булган депутатлар төркеме эшли.

2000 нән социаль әһәмияткә ия инициативаларны тормышка ашыруда ярдәм итү «Т. – Я.г.» эшчәнлегендә өстенлекле юнәлешләрнең берсен тәшкил итә. 2001 нең апрелендә «Т. – Я.г.» ның актив катнашлыгы б-н төп максаты җәмгыятьтә һәм хакимият структураларында кеше һәм табигатьнең үзара гармонияле бәйләнештә булу идеясен популярлаштыру булган «Җир хартиясе» халыкара конференциясе үткәрелә. Аның принциплары БМОның рәсми документында — «Җир хартиясе»ндә баян ителә. 2002 дән кече һәм урта бизнеска дәүләт булышлыгы мәсьәләләренә игътибар бирелә башлый. «Т. – Я.г.»ның Яшьләр берләшмәсе 2004 нең 3 мартында Бөгелмә шәһәрендә респ-ка яшьләр форумы үткәрү инициаторларының берсе була, анда ТР Дәүләт Советы каршында консультатив орган — Иҗтимагый яшьләр палатасы (2004 нең апрелендә оештырыла) булдыру карала.

2001 дә «Сәяси партияләр турында» Федераль Закон кабул ителү һәм 2001–02 дә «Бердәм Россия» партиясенең Татарстан төбәк бүлеге оештырылу б-н «Т. – Я.г.» хәрәкәте акрынлап элеккеге сәяси абруен югалта башлый. «Т. – Я.г.»ның кайбер активистлары «Бердәм Россия» партиясен оештыруда катнаша, 2003 нең августында «Т. – Я.г.» сәяси советы рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшин «Бердәм Россия» партиясенең Татарстан бүлеген җитәкли башлый. Шуннан соң «Т. – Я.г.» үз эшчәнлеген «Бердәм Россия»нең сәяси союздашы буларак алып бара. Хәрәкәттә катнашучыларның күбесе яңа «хакимият партиясенә» керәләр, анда җитәкче урыннарны били, «Бердәм Россия» партиясеннән депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелә (мәс., 2003 тә РФ Дәүләт Думасына сайлауларда Ф.И.Гайнуллина, И.И.Гыйльметдинов, В.Н.Ельцов, М.Р.Рокицкий, Ә.А.Кармиев, М.Ф.Мәһдиев депутат булып сайланалар).ТРның 3 нче чакырылыш (2004–09) Дәүләт Советы составында «Т. – Я.г.» ның депутатлар төркеме барлыкка килә (12 депутат, координатор М.Г.Галиев), ТРның 4 нче чакырылыш (2009–14) Дәүләт Советы составында «Т. – Я.г.»ның депутатлар төркеме барлыкка килә (13 депутат, координатор Р.З.Закиров). 2005 тә ТР муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнарына сайлауларда «Т. – Я.г.»дан тәкъдим ителгән 1713 кандидат депутат булып сайлана.

«Т. – Я.г.»ның символлары: зәңгәрсу түгәрәккә ТР терр-ясенең контурлары төшерелгән, уң яктан үсә бару тәртибендә дәүләт флагы төсләренә (яшел, ак, кызыл) буялган 3 өчпочмак куелган, әйләнәсенең тышкы ягына рус һәм татар телләрендә хәрәкәтнең исеме язылган эмблема; ак полотно үзәгендә хәрәкәт эмблемасы сурәтләнгән флаг.

*Әд.:* Терентьева И.В., Беляков Р.Ю., Сафаров М.Ф. Республика Татарстан: политические партии, движения, лидеры. К., 2003; Сафаров М.Ф., Ягафарова Д.С. К гражданскому обществу — развивая гражданские инициативы: Информационно-аналитические материалы в помощь активу РОПД «ТНВ» — «ТЯГ». Альметьевск, 2004.

*М.Ф.Сәфәров.*

**«ТАТАРСТА́Н ЯШЬЛӘРЕ́»**, респ-ка яшьләр газетасы. 1920 елның 22 гыйнварыннан Казанда татар телендә нәшер ителә. Оештыручылары — ТР Яшьләр оешмалары советы, «Татарстан яшьләре» плюс» нәшрият йорты коллективы. Башта Россия коммунистик яшьләр союзы Казан губерна ком-тының мөселман бюросы газетасы, аннары ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты органы буларак басыла, 1920–38 елларда — «Кызыл яшьләр», 1938–56 да — «Яшь сталинчы», 1956 дан «Т.я.» исемендә чыга. Басма 1942 нең 24 мартында чыгудан туктый, 1949 ның 21 августында кабат тергезелә. Төрле еллардагы мөхәррирләре — Г.*Кушаев*, М.*Парсин*, В.*Шәфигуллин*, Ш.*Рәмзи*, С.Фәхриев, Л.Гомәров,




Ш.Фәхретдинов, Ф.Мөбарәкшин, Б.*Корбанов*, И.*Гази*, Х.Бәдри, Р.Хәмиди, Х.Исмай, Г.Дәүләтшин, Я.Насыйров, Г.*Хуҗи*, Р.*Тимергалин*, И.*Беляев*, Б.*Камалов*, С.Гарипов, Җ.Кәлимуллин, И.*Әхмәтҗанов*, Ш.Зәбиров, Х.*Әшрәфҗанов*, Х.Гайнуллин, 1990 нан — И.*Шәрәфиев*. Газета формалашып китүгә З.Баширова, И.Гази, З.Зәмирова, С.Фәхриев, Ш.Фәхретдинов, Т.Ченәкәй (Т.Гыйззәтуллин) зур көч куя. Гражданнар сугышы чорында яшьләрнең фронтта һәм тылдагы батырлыкларына, халык хуҗалыгын аякка бастырудагы, ачлык һәм җимереклекләргә каршы көрәшүдәге роленә зур игътибар бирелә. 1923 тә «Яшь инкыйлабчы җырлары» җыентыгы басыла. Кушымталар дөнья күрә: 1925–29 да «Яшь хәбәрчеләр авазы» (3 сан), 1932 дә «Кызыл яшьләр», «Бөреле совхозында», «Кызыл яшьләр» чәчүдә». Беренче бишьеллыклар комсомол ячейкалары эшенә, яшь эшчеләр һәм батракларның көнкүрешен яхшырту, аларны проф. оешмаларга җәлеп итүгә багышланган материаллар басыла. Наданлыкка каршы көрәшкә, татар кызларын комсомол тормышына җәлеп итүгә, дингә каршы пропагандага зур урын бирелә; ТАССРда балалар хәрәкәтен күтәрү, яшь хәбәрчеләрне газетага эшкә тарту игътибар үзәгенә алына. Сугышка кадәрге чорда төп темалар арасында комсомол төзелешләре, колхозлар оештыру һәм авыл тормышын үзгәртеп кору, мәдәният һәм мәгариф үсеше, яшьләрне хәрби-патриотик әзерләү була. Әдәбият почмагында яшь эшче һәм крәстияннәрнең беренче иҗат тәҗрибәләре басыла. Газетада күренекле язучылар Ф.Кәрим, Г.Минский, Һ.Такташ һ.б. эшли, Ф.Хөсни, Г.Кутуй, Ә.Еникинең иҗади эшчәнлеге «Т.я.»ннән башлана. К.Әмири, Н.Баян, М.Җәлил, М.Максуд, Ш.Усманов, Г.Толымбайский, Х.Туфан һ.б. әсәрләрен бастыралар. Татар коммунистлар ун-ты укучылары Р.Әхмәтшина, Г.Гали, Т.Еналиева, Б.Ильясова, М.Мохтасаров, К.Рәхим, Ш.Салаватов газетаның актив авторлары була. 1949 да басма кабат чыга башлагач, анда Г.Хуҗи, Г.Насрый, Ш.Мөдәррис, С.Урайский эшли, газета б-н И.Беляев, Г.Сәгыйдуллин, М.Садри, Җ.Фәйзи, Н.Дәүли, М.Ногман, Г.Латыйп хезмәттәшлек итә. «Т.я.» дип атала башлагач, аның форматы зурая, тиражы 15 мең данәгә җитә. Газетада комсомолларның халык хуҗалыгын торгызу һәм үстерүдә катнашуы, Татарстанның нефть чыганаклары үзләштерелә башлау, беренче комсомол-яшьләр бригадаларының хезмәте, көнкүреше һәм нефть табу тармаклары турындагы мәкаләләр урын ала. Вакыт шаукымына ияреп, дөньяга коммунистик караш, социализм дошманнары б-н килешмәүчәнлек пропагандалана. Соц. ярышта актив катнашу хуплана, «Язгы чәчү батыры», «Икмәк фронты герое» һ.б. исемнәр өчен көрәш, егет-кызларның авыл җирендә хезмәт һәм көнкүреш культурасын үстерүдәге эшчәнлеге, яшьләрнең белемнәрен һәм техник дәрәҗәләрен күтәрүләре, фәнни-техник прогресста катнашулары киң яктыртыла. Вакытлар узу б-н, җитештерүгә һәм иҗтимагый-сәяси темаларга кагылышлы язмалар б-н беррәттән социаль темаларга да очерклар басыла, яшь кешенең эчке дөньясына игътибар көчәя. Газета 1990 елларда аеруча популярлык казана, ул чорда анда яшьләр өчен көн кадагында булган темалар күтәрелә башлый. Татар телендәге әйдәп баручы яшьләр газетасы яшь журналистлар һәм әдәбиятчылар мәктәбе, респ-каның иң күп тиражлы һәм укыла торган татар вакытлы матбугаты булып кала.

*Әд.:* Баширова З.Х. Первая татарская молодёжная газета // Страницы славного прошлого комсомола Татарии. К., 1958.

*Р.А.Айнетдинов.*

**ТАТАРСТАНДА́ А́ТОМ-ТӨШ КОРЫЛМАЛАРЫНА́ КАРШЫЛА́Р ҖӘМГЫЯТЕ́**, җәмәгать оешмасы. 1989 елның ноябрендә Казанда оештырыла (1990 ның мартында рәсми теркәлә). Лидерлары: А.Ф.Гарапов (Гарәфов), М.Г.Кадыйров, В.М.Галков, В.А.Гончаров, А.З.Закиров, С.П.Гаврилов һ.б. Югары җитәкче органы — конференция, башкарма оешмасы — идарә. Матбугат басмалары — «Мәһди» электрон бюллетене. Программалары: киң җәмәгатьчелекне экологик-энергетик проблемаларны хәл итүгә өндәү, атом электр станцияләрен төзүне тыю, төзелгәннәренең ябылуына ирешү, экологик яктан чиста булган электр корылмалары технологияләрен үзләштерүне һәм аларны кулланылышка кертүне хуплау. Җәмгыятьнең гамәли эш-

чәнлеге атом электр станцияләрен (АЭС) файдалану һәм аларның табигатькә, ш.у. кешегә тәэсире, экологик яктан чиста булган һәм электр корылмалары технологияләрен үзләштерү, мәгълүмати фонд оештыру, АЭС төзелешенә һәм радиоактив калдыкларга каршы протест йөзеннән марш оештыру өлкәсендә тикшеренүләр үткәрүдән гыйбарәт (1989 ның 1–2 июлендә Бөтентатар иҗтимагый үзәге һәм экология оешмалары катнашы б-н СССРда Татарстан һәм Башкортстан АЭС төзелешенә каршы протест акциясе үткәрелә). Т.а.-т.к.к.ж. башлангычы б-н Бөтенсоюз атом-төш корылмаларына каршы конференцияләр («Антиядерное движение: проблемы и альтернативы ядерной энергетики и промышленности», 1990, 1996 һәм 2000, Казан) үткәрелә. Элеккеге СССРның күп кенә шәһәрләреннән килгән делегатлар илдәге барлык атом-төш корылмаларына каршы көчләр консолидациясе, атом-төш корылмаларына каршы координацион үзәк төзү, барлык АЭСларны төзүне туктату, башка илләрдән кергән атом-төш корылмалары калдыкларын СССРда күмүне тыю, яңа энергетика программасын эшләүдә ярдәм итү, илдәге экологик халәт турында халыкка мәгълүмат бирү, чит илләргә ягулык экспортын киметү мәсьәләләрен тикшерәләр. 2 нче конференциядә ш.у. исерткеч эчемлек һәм тәмәке рекламалауны тыю, Татарстанда битум чыгаруны туктату, химик коралларны юк итү технологиясен җентекле экологик тикшерү мәсьәләләре күтәрелә. 3 нче конференциядә катнашучылар Евразия атом-төш корылмаларына каршы көрәшнең «яшел хәрәкәт»ен, Казанда һәм Новосибирскида координацион үзәкләре булган бердәм компьютер челтәре булдыру мәсьәләсен күтәрәләр.

*Әд.:* На путях к духовно-экологической цивилизации. Евразийский проект. К., 1996.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ТАТАРСТАНДА́ ИҖТИМАГЫ́Й-СӘЯСИ́ ОЕШМАЛА́Р ҺӘМ ХӘРӘКӘТЛӘ́Р**. Беренче оешмалар һәм хәрәкәтләр 19 йөзнең 2 нче яртысында – 20 йөз башында формалаша, алар арасында народниклар (к. *Народниклык*), социал-демократлар (к. *Советлар Союзы Коммунистлар партиясе*), шәкертләр (к. *Шәкертләр хәрәкәте*), вәисиләр (к. *Вәисиләр хәрәкәте*), анархистлар (к. *Анархизм*), хатын-кызлар (к. *Хатын-кызлар хәрәкәте*) һ.б. оешмалар һәм хәрәкәтләр була. Иҗтимагый тормышта земство оешмалары (к. *Земство*) зур роль уйный. Татар милли хәрәкәте формалашуга *мәгърифәтчелек* һәм *җәдитчелек* йогынты ясый. 20 йөз башында беренче *сәяси партияләр* формалаша башлый. Кайбер иҗтимагый-сәяси эшлеклеләр хәйрия оешмаларына ышыкланып эш йөртәләр (к. *Приказчиклар хәйрия җәмгыяте*). 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң яңа оешмалар: социалистик (*Мөселман социалистлар комитетлары* һ.б.), хакимият яклы (*«Җәмәгать иминлеге комитетлары»*, *Социалистик оешмалар берлеге*, *«Ватан һәм азатлыкны саклау берлеге»* һ.б.), татар милли-демократик (*Милли Шура, Хәрби Шура, Мөселманнар комитеты* һ.б.), яшьләр оешмалары (*Эшче яшьләр берлеге, Мөселман яшьләре түгәрәге* һ.б.) һ.б. барлыкка килә. Совет чорында иҗтимагый-сәяси оешмалар эшчәнлеге хакимият тарафыннан катгый контрольдә тотыла. КПСС, *Бөтенсоюз ленинчыл коммунистик яшьләр союзы* (ВЛКСМ), В.И.Ленин исем. Бөтенсоюз пионерлар оешмасы һ.б. рәсми рәвештә танылган оешмалар булалар. Шул ук вакытта совет хакимиятен һәм коммунистик идеологияне танымаган оешмалар эшчәнлеге тыела (мондый оешмалар ачыктан-ачык яшерен яки ярым яшерен рәвештә бары тик 1920 еллар башында һәм 1980 еллар ахырында гына эшлиләр).

1980 еллар ахырыннан төрле оешмалар һәм хәрәкәтләр оештырыла, аларның максаты җәмгыятьнең сәяси тормышында (сайлауларда, дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары формалашуда) катнашу була. Социаль-сәяси фәннәрдә «иҗтимагый-сәяси оешмалар һәм хәрәкәтләр» төшенчәсенең киңәйтелгән аңлатмасы өстенлек ала – оештыру-хокук формаларына карамастан, сәяси мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән барлык иҗтимагый оешмалар (партияләр, хәрәкәтләр, берлекләр, ассоциацияләр). 2001 гә кадәр мондый аңлатма иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген көйләүче Россия законнарында, ш.и. СССР (1990) һәм РФнең (1995) «Иҗтимагый оешмалар турында» законнарында кулланыла. 1998 гә кадәр либераль мөнәсәбәт хөкем сөрә, ягъни эшчәнлекләренең терр. сфераларына (гомумроссия, төбәк, җирле) карамастан, барлык иҗтимагый оешмалар, ш.и. профсоюзлар һәм иҗтимагый фондлар, сәяси эшчәнлек алып барып, теркәлгән очракта дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарындагы сайлаулы вазифаларга кандидатлар тәкъдим итә алалар. 1998 дә законнарга «сәяси иҗтимагый оешма» аңлатмасы кертелә һәм турыдан-туры сәяси эшчәнлек алып бару хокукы булган иҗтимагый оешмалар даирәсе өлешчә чикләнә (мондый хокуктан профсоюзлар һәм иҗтимагый фондлар мәхрүм ителә). Шул ук вакытта сәяси партияләр, хәрәкәтләр, оешмалар, берлекләр, ассоциацияләр сәяси эшчәнлек алып бару хокукын саклыйлар (әгәр бу аларның уставларында чагылса яки аларның рәсми атамаларында әлеге эшчәнлеккә туры килә торган билгеләмә булса).

2001 дә партияләр системасында реформалар башлау кысаларында РФнең «Сәяси партияләр турында» Федераль законы кабул ителә, сәяси эшчәнлек алып бару хокукы бары тик гомумроссия сәяси партияләренә генә бирелә (төбәкләрдәге сәяси партияләр тыела). Сәяси булмаган башка иҗтимагый оешмалар (партиянеке булмаган) федераль һәм төбәкләрдәге сайлауларда теге яки бу партиягә ярдәм итәргә мөмкиннәр, ш.у. муниципаль хакимият органнарына кандидатлар тәкъдим итә алалар. Шулай да рәсми рәвештә сәяси булмаган күп кенә иҗтимагый оешмалар, асылда, иҗтимагый-сәяси оешмалар булып калалар. Дәүләт хакимияте органнарындагы сайлаулы вазифаларга мөстәкыйль рәвештә кандидатлар күрсәтү мөмкинлеген югалтып, алар җәмгыятькә һәм хакимият структураларына идеологик йогынты ясауларын, халык җәлеп ителгән сәяси чараларда (демонстрацияләр, митинглар, пикетлар һ.б.) катнашуларын дәвам итәләр.

1980 еллар ахырында коммунистик режим либеральләшү процессында төрле идеологик ориентацияле иҗтимагый-сәяси оешмалар эшчәнлеген җәелдерү өчен реаль шартлар барлыкка килә. Аларның күбесе 1970–80 елларда яшерен рәвештә эшләгән формаль булмаган иҗтимагый структуралар нигезендә формалаша. СССРдагы кебек үк, ТАССРда беренче легаль иҗтимагый-сәяси оешмалар 1980 еллар ахырында экологик хәрәкәт (к. *«Татарстанда атом-төш корылмаларына каршылар җәмгыяте»*) һәм КПССның «үзгәртеп кору» курсын яклау хәрәкәте кысаларында барлыкка килә башлый. Әлеге хәрәкәтләр юнәлешендә баштарак социалистик нормалар кысаларында, соңрак социализмнан баш тарту юлы б-н сәяси системаны демократияләштерүне таләп иткән оешмалар төзелә: Татарстан АССР Халык фронтының инициатив үзәге (1988), Татарстанны радикаль үзгәртеп кору хәрәкәте (1989), Татарстанның демократик көчләре координацион советы (1990). Шул ук елларда Татарстанда 2 идеологик агым башлангыч ала (алар йогынтысының иң югары ноктасы 1990 елларга туры килә): татар милли хәрәкәте һәм федералистик демократик хәрәкәт. 1980 еллар ахырында татар иҗтимагый-сәяси оешмаларның төп максатлары – татар милләтен торгызу һәм берләштерү, татар теленең һәм мәдәниятенең тигез хокуклылыгы, ТАССР статусын союздаш респ-ка дәрәҗәсенә күтәрү. 1990 еллар башында таләпләр тагын да кискенләшә, РФ б-н шартнамәләргә (конфедератив) нигезләнгән мөнәсәбәтләрне күздә тоткан респ-ка суверенлыгы идеясе барлыкка килә, кайбер оешмалар Татарстанның тулысынча сәяси бәйсезлеген яклыйлар. Татар милли хәрәкәтендә беренче һәм аеруча зур иҗтимагый-сәяси оешма булып Татар иҗтимагый үзәге (1988), соңрак *Бөтентатар иҗтимагый үзәге* санала. 1990 елларда татар иҗтимагый-сәяси оешмаларның күбесе, ш.и. *Татар милли бәйсезлек партиясе «Иттифакъ»*, *«Азатлык» татар яшьләре берлеге*, «Суверенитет» ком-ты (барысы да – 1990 да), аның активистлары тарафыннан формалаша. 1992 дә *Милли Мәҗлес* – законнар чыгару функциясен өлешчә гамәлгә ашыруны дәгъва кылучы оешма, Татарстан Республика партиясе, ш.у. *Бөтендөнья татарлары конгрессының башкарма комитеты* оештырыла. 1990 елларда татар милли хәрәкәт кысаларында радикаль һәм урталык идеологик агымнары формалаша. Радикалларның мәнфәгатьләре, башлыча, Татарстан җитәкчелегенә оппозициядә булган «Иттифакъ» партиясе эшчәнлегендә чагыла. Респ-каның рәсми хакимиятенә лояль урталык агымы вәкилләре 1992 дән, башлыча, Бөтендөнья татар конгрессының башкарма ком-тына ориентлашалар. Ике агым да федераль хакимият органнарының Татарстанга карата мөнәсәбәттә эшчәнлегенә теге яки бу дәрәҗәдә тәнкыйди карый. Федералистлар демократик

хәрәкәте РФнең хакимият һәм сәяси структураларына ориентлашалар. Ул ике төрдәге оешмадан тора: респ-ка партияләре һәм хәрәкәтләре, гомумроссия партияләре һәм хәрәкәтләренең төбәк бүлекләре. Идеологик мөнәсәбәттә либераль һәм с.-д. юнәлештәге оешмалар өстенлек алалар. Аларның кайберләре этаплап демократияләштерү һәм шуннан соң КПСС таралу нәтиҗәсендә барлыкка килә: 1990 да — «КПССта демократик платформа» (соңрак — Россиянең Республика партиясе), 1991 дә — «Коммунистлар демократия өчен» (соңрак — «Ирекле Россия» халык партиясе») оештырыла; ике партия дә — с.-д. идеологиясе тарафдарлары. Башка оешмалар КПССтан тыш төрле формаль булмаган структуралар: «Демократик Россия» хәрәкәте, Россия демократик партиясе, Россия с.-д. партиясе һ.б бүлекләр җирлегендә формалашалар. Киң коалиция һәм блоклар кысаларында (мәс., «Тигез хокуклылык һәм законлылык» сайлау блогына, 1993) Мәскәү яклы оешмаларны берләштерү омтылышлары була. Соңрак мондый юнәлештәге оешмалар арасында аеруча йогынтылылары буларак «Яблоко» берләшмәсенең (соңрак партиясенең) һәм «Россиянең демократик сайлау» партиясенең төбәк бүлекләре танылა. 1990 еллар башында, СССР таркалганнан соң, яңа җирлектә 1991–92 дә ТР Коммунистлар оешмасы (к. *Россия Федерациясе коммунистлар партиясенең Татарстан региональ булеге* (РФКПТРБ)) буларак рәсмиләштерелгән коммунистлар хәрәкәте формалаша башлый. 1993 тә респ-ка хакимият структуралары җитәкчелегендә Татарстанның «Бердәмлек һәм прогресс» партиясе оештырыла. 1995 тән респ-ка хакимиятенең сәяси мәнфәгатьләрен «Россия — безнең йорт» хәрәкәтенең Татарстан оешмасы, 1999 дан «Татарстан — Яңа гасыр» респ-ка иҗтимагый-сәяси хәрәкәте, 2001 дән «Бердәм Россия» партиясенең Татарстан төбәк бүлеге чагылдыра. Шулай итеп, 1990 еллар уртасына респ-каның партия-сәяси мәйданына татар милли, федералистик (Мәскәү яклы), коммунистик, ш.у. респ-ка җитәкчелеген яклаучы оешмалар чыга. Мондый хәл 2000 елларда үзгәрә башлый. Рус милләтчелеге лозунглары астында эш иткән оешмалар халык тарафыннан яклау таба алмый. Оешмаларның күбесе эшчәнлеген туктата. Эшләп килүче иң әһәмиятлеләре: Бөтентатар иҗтимагый үзәге, «Тигез хокуклылык һәм законлылык» оешмасы, «Татарстан — Яңа гасыр» хәрәкәте.

*Әд.:* Терентьева И.В., Беляков Р.Ю., Сафаров М.Ф. Политические партии и движения Республики Татарстан. К., 1999; шулар ук. Республика Татарстан: Политические партии, движения, лидеры. К., 2003.

*М.Ф.Сәфәров.*

**ТАТАРСТАНДА́ 1918–54 ЕЛЛА́Р РЕПРЕ́ССИЯЛӘРЕ**, СССРның җәза бирү органнары (төрле елларда ВЧК, ОГПУ, НКВД, НКГБ, МГБ, МВД, КГБ) тарафыннан совет режимы дошманнарын (башлыча, ялган «халык дошманнары» һәм «корткычлык кылучылар»ны) юк итү, концлагерьларга һ.б. административ ябып тоту урыннарына озату рәвешендә максатчыл төстә алып барылган сәясәт. Репрессияләрнең төп механизмы сәяси суд процесслары (күбесенчә ялган рәвештә махсус) оештырудан гыйбарәт, ләкин еш кына физик юк итү судсыз һәм тикшерүсез башкарыла. Репрессияләр Гражданнар сугышы елларында кызыл террор (к. *Кызыл һәм ак террор*) формасында башлана; беренче хезмәт белән тәрбияләү лагерьлары (Зөядәге лагерь 1918 елда ачыла, соңрак — «Волжлаг»; Казан лагере, 1919) оештырыла. Авылларда крәстиян хуҗалыкларын көчләп күмәкләштерү барышында репрессияләр массакүләм төс ала, бигрәк тә крәстияннәр көчлезыян күрә (к. *Кулакларны йорт-җирләреннән куу*). Татарстанда совет хакимияте урнашкан вакыттан башлап репрессияләргә эзлекле рәвештә төрле дин вәкилләре дучар ителә (к. «*Ислам баласы*», «*Раифа монастыре*» *эше, Раифа шәһидләре*). 1929–38 дә репрессияләр җәмгыятьнең барлык катлауларына кагыла; «өчлекләр» (судсыз репрессия органы) карары б-н күпләп атулар һәм ГУЛАГ системасында мәҗбүри хезмәт куллану аңарчы күрелмәгән күләмнәрдә гамәлгә ашырыла. СССРда сәяси репрессияләрнең аеруча киң колач алуы 1937 нең 2 июлендә И.В.Сталин тарафыннан эчке эшләр халык комиссары Н.И.Ежовка, НКВД органнарына үз карамакларыннан чыгып аерым гражданнарның хакимияткә «дошман булуын» билгеләүгә һәм ике категориягә бүлеп (беренчесе — атылырга тиешлеләр, икенчесе — «дошманлыгы азрак булган» затлар, ГУЛАГ лагерьларына җибәрелергә тиешләр) исемлек төзү мәсьәләсендә зур вәкаләтләр тапшырылган күрсәтмә бирелгәннән соң, 1937 гә туры килә. 1937–38 дә Татарстанда 11806 кеше кулга алына, 3166 кеше атып үтерелә (кулга алынганнарның гомуми исәбеннән 26,8%). НКВД каршындагы «өчлек» 28 утырыш барышында (1937 нең 6 августыннан башлап 1938 нең 8 гыйнварына кадәр) 2570 кешене атарга, 2792 кешене лагерьларга ябарга карар чыгара. 1936–38 дә Мәскәүдә Коммунистлар партиясенең элеккеге җитәкчеләре, хәрби башлыклар, интеллигенция өстеннән барган сәяси процессларда махсус модель булдырыла, шул модель буенча «фетнә» («заговор»), «контрреволюцион оешмалар һәм төркемнәр» турында барлык җирле эшләр оештырыла. Контрреволюцион җинаятьләрдә гаепләүләрнең иң киң таралганнары (РСФСРның Җинаять кодексында 1922 – 57–66 маддә, 1926 – 58 маддә, 1–14,59 пунктлар) — шпионлык (58 маддә, 6 п.), корткычлык (58 маддә, 7 п.), хакимият вәкилләренә каршы террорчылык актлары әзерләү (58 маддә, 8 п.), совет хакимиятен таркату һәм бәреп төшерүгә өндәгән пропаганда. 1930 елларда — 1940 еллар башында ТАССРның һәм СССРның ОГПУ органнары дистәләрчә ялган гаепләү «эшләрен» оештыралар, алар арасында — «*Буржуаз милләтчеләрнең совет хакимиятенә каршы оешмасы*» эше, «*Совет властена каршы оешкан төркем*» эше, «*Милләтчеләрнең совет хакимиятенә каршы оешмасы*» эше, «*Атласов*» эше, «*Идел-Уралчылар оешмасы*» эше, «*Немецларның контрреволюцион-фашистик оешмасы*» эше, «*Контрреволюцион фетнәчеләр оешмасы*» эше, «*Троцкийчыларның контрреволюцион төркеме*» эше, «*Троцкийчы милләтчеләрнең контрреволюцион-террорчылык оешмасы*» эше, «*Троцкийчыларның контрреволюцион-террористик оешмасы*» эше, «*Солтангалиевчеләрнең Мәскәү үзәге*» эше, «*Милләтчеләрнең контрреволюцион-фетнәчел оешмасы*» эше, «*Немецларның совет хакимиятенә каршы фетнәчел оешмасы*» эше, «*Уң троцкийчы милләтчеләрнең совет хакимиятенә каршы оешмасы*» эше.

1918–54 тә Татарстанда 150 меңгә якын кеше — күренекле сәясәт эшлеклеләре, дәүләт һәм партия учреждениеләре хезмәткәрләренең зур өлеше, фән һәм мәдәният эшлеклеләре, крәстияннәр һәм эшчеләр репрессияләнә. 1953 тән соң 1930 еллардагы сәяси процесслар яңадан карала. Репрессия корбаннарының күпчелеге совет хакимиятенең 1954 тәге, 1989 дагы һәм 1990 дагы карарлары б-н аклана (к. *Репрессияләнүчеләрне аклау*).

*Әд.:* Литвин А.Л. Запрет на жизнь: Сталинские репрессии в Татарстане. К., 1993; шул ук. Красный и белый террор в России. 1918–1922 гг. К., 1995; Стецовский Ю.И. История советских репрессий: В 2 т. М., 1997; Степанов А.Ф. Расстрел по лимиту: Из истории политических репрессий в ТАССР в годы «ежовщины». К., 1999; Султанбеков Б.Ф. Политические репрессии 30-х годов: Законы, исполнители, реабилитация. К., 1999.

*Р.Р.Батыршин.*

**ТАТАРСТАННЫ́ ГЫЙЛЬМИ́ ӨЙРӘНҮ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, төбәкне өйрәнү оешмасы. ТАССР ХКСның 1928 ел 12 сентябрь карары нигезендә *Гыйльми үзәкнең* 1928 нең 1 августында гамәлдән чыгарылган Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросына алмашка оештырыла; ТАССРны, ш.и. мәдәниятне һәм халыкның көнкүрешен комплекслы өйрәнү буенча киң колачлы тикшеренү мәсьәләләре б-н шөгыльләнгән массачыл оешма. Т.г.ө.җ. респ-када төбәкне өйрәнү хәрәкәтен координацияләүче төп органга әверелә. Җәмгыятьне оештыруга 3 нче Бөтенроссия төбәкне өйрәнү конференциясенең (1927) төбәкне өйрәнү эшен соц. төзелешнең гомуми планына кертүне күздә тоткан карарлары этәргеч бирә. Әзерлек эшләре б-н оештыру ком-ты шөгыльләнә: рәисе — И.Ш.Рәхмәтуллин (Мәгариф халык комис-тыннан), аның урынбасары — Н.-Б.З.Векслин (Дәүләт план ком-тыннан), гыйльми секретарь — Р.Ш.Таһиров (Шәрекъ пед. ин-тыннан). Баштарак *Татар мәдәнияте йорты* карамагында, 1930 дан *Татарстан икътисад фәнни-тикшеренү институты* җитәкчелегендә эшли. Т.г.ө.җ. эшчәнлеге чорында 11 шәһәрдә, ш.у. респ-ка волостьларының кайберләрендә (Минзәлә, Чаллы, Зөя, Бөгелмә шәһәрләрендә, Лаеш, Кукмара, Тәмте, Әлки авылларында һ.б.) җирле бүлекчәләр челтәре булдырыла. Җәмгыять төрле өлкәләрдә зур белгечләр, галимнәр җитәкчелегендә һәм алар ярдәме б-н җирле төбәкне өйрәнүче кадрлар әзерләү мәсьәләсен бурыч итеп куя. Җәмгыятьнең идарәче һәм башкарма органы 2 елга сайланулы үзәк советтан (рәисе И.Ш.Рәхмәтуллин) һәм 7 кешедән торган президиумнан гыйбарәт була. Үзәк совет 10 секцияне берләштерә: сәнәгать-икъ-

тисад; а.х.; урманчылык; транспорт һәм элемтә; табигать; атмосфера, туфрак, җир асты байлыклары һәм су; мәдәният һәм көнкүреш; медицина; музейлар; фотография. Үзәк совет пленумы кимендә елга 1 тапкыр чакырыла. Җәмгыятьнең төп өйрәнү объектлары — табигать һәм аның казылма байлыклары, икътисад, көнкүреш, респ-ка халкының физик халәте. Җәмгыять респ-кадан читтә яшәгән татар халкының тормышын төрле яклап өйрәнү мөһимлеге мәсьәләсен күтәргән бердәнбер оешма була; татарларның таралып урнашуының тулы этнографик картасын төзү һәм әлеге төркемнәрне өйрәнү күздә тотыла. Мәдәният һәм көнкүреш секциясе бик актив эшли, ул тарих, археол. һәм этнография мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. Кульъязмалар, төрле чорларга караган кабер ташлары тарихын өйрәнүгә, кабер ташлары язмаларын теркәүгә һәм риваятьләр җыюга зур әһәмият бирелә. Төбәктә яшәгән аерым халыкларның үзара мөнәсәбәтләре, Идел буенда татарлар һәм болгарлар урнашу мәсьәләләре ачыклана. Секция, уртак карашлардан чыгып, төбәк тарихы буенча мөһим темаларны билгели: «Урта һәм Түбән Идел буе тарихы»(Н.Н.Фирсов), «Казан хәрби округы» (Н.Ежов), «Казан төбәгендә крәстияннәр кузгалышлары тарихы». Т.г.ө.җ.нең төп эш формасы аерым районнарны планлы рәвештә өйрәнү өчен комплекслы экспедицияләр оештырудан гыйбарәт була. Һәр экспедициядә археол., тарих, тел белеме, фольклор, этнография, сәнгать белгечләре катнаша. 1929 да мәдәният һәм көнкүреш секциясе 2 этнографик-лингвистик экспедиция оештыра (Җ.Вәлиди һәм Н.И.Воробьёв — Түбән Новгород өлкәсендә яшәүче карин һәм глазов татарлары төркемнәрен өйрәнү максаты б-н; Т.Чернәкәй — Оренбург өлкәсенә һәм Башкортстанга татар фольклорын җыю өчен). Шул ук елда Бөгелмә р-ны Урыссу авылында археол. эзләнүләр һәм каберлекләрне казып тикшерү эшләре башкарыла. П.Е.Корнилов болгар-татар каберлекләрен һәм авыл сәнгатен өйрәнә, Н.Ф.Калинин һәм М.Г.Худяков Борисково авылы янындагы Пыяла з-ды урынында археол. эзләнү һәм Биләр шәһәрлеген топографик яктан өйрәнү эшләре алып бара. Җәмгыять, Музейлар, борынгы истәлекләрне саклау һәм табигать эшләре бүлеге б-н берлектә Н.Ф.Калинин, В.В.Егерев, З.Акчурина һ.б. катнашында Казан Кремлендә археол. казу эшләре уздыра. Ул респ-ка терр-ясендә археол. тикшеренүләр вакытында А.С.Башкиров һәм В.Н.Сементовский җитәкчелегендәге Шәрекъ халыклары ин-ты һәм Шәркыять белеме фәнни ассоциациясе б-н хезмәттәшлек итә. 1928–29 да Җәмгыять тарафыннан ТАССР һәм РСФСРның төрле учреждениеләре һәм оешмалары күрсәтмәләре буенча 34 экспедиция оештырыла; экспедиция нәтиҗәләре буенча гамәли конференцияләр уздырыла. Экспедиция эшчәнлеге нәтиҗәләре «Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте Үзәк советының таныштыру бюллетене»ндә («Осведомительный бюллетень Центрального совета Общества изучения Татарстана», 1929, № 1–3) басыла. Җәмгыять тарафыннан 3 журнал, ш.и. төбәк тарихын чагылдырган фәнни-популяр «Татарстан» ж-лы нәшер ителә (1929 дан). Аерым басмалар да чыга, мәс., Г.Рәхимнең «Авыл тарихын монографик тасвирлау методикасы» («Методика монографического описания истории села», 1930) дөнья күрә. 1930 да 3 томда «Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте хезмәтләре» («Труды общества изучения Татарстана») басыла (1 нче том тарих, этнография, археол. һәм татар теле мәсьәләләренә багышлана). Материалларның бер өлеше 1929 да Т.г.ө.җ.нә кушылган *Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте* әгъзалары тарафыннан әзерләнә. Мәдәният һәм көнкүреш секциясе татар телендәге фәнни терминнарны җыю, татар теленең орфографиясен эшләү буенча эш алып бара, Җ.Вәлидинең «Татар теленең тулы сүзлеге»н (1–2 кис., 1927–29) төзүдә, ш.у. Зур совет энциклопедиясенә материаллар әзерләүдә катнаша. Җәмгыять 1920–30 елларда Татарстанда музей эшләре үсешендә зур роль уйный. Т.г.ө.җ.н Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте б-н бергә кушканнан соң, мәдәният һәм көнкүреш секциясенең эше активлаша. Кыска гына вакыт эчендә Т.г.ө.җ. төбәкне өйрәнүче көчле үзәккә әверелә, ул татар халкы тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертә. Төбәкне өйрәнүче оешмалар б-н көрәш чорында 1931 дә җәмгыятьнең эшчәнлеге туктатыла.

*Әд.:* Векслин Н.Б. Изучение Татарстана за 10 лет (1920–1930) // Очерки по изучению местного края. К., 1930; Фёдорова Н.А. К истории Общества изучения Татарстана // Народы Среднего Поволжья: История, культура. К., 1993; Зайцев А.В. Исторические учреждения Республики Татарстан в 20–30-е годы XX века. К., 1998.

*А.В.Зайцев.*

**ТАТАРСТАННЫ́Ң СОЦИАЛИ́СТИК ТӨЗЕЛЕ́Ш БАТЫРЫ́**, 1931–1935 елларда ТАССРда мактаулы исем. ТАССР ҮБК һәм ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты тарафыннан булдырыла. Фидакарь хезмәт күрсәтүчеләргә, җитештерү өлкәсендә аеруча зур казанышларга ирешүчеләргә, илдәге иҗтимагый-сәяси тормышта актив катнашучыларга ТАССР ҮБК Президиумы тарафыннан (ТАССР ҮБК грамотасын тапшыру б-н бергә) бирелә. Беренче тапкыр 1931 нең 30 апрелендә ТАССР ҮБК карары б-н массакүләм соц. ярышның 2 еллык бәйрәмен билгеләп үтү йөзеннән җитештерү алдынгыларына бирелә. Бу исемгә якынча 170 кеше лаек була.

*Әд.:* Герои Труда Татарии. К., 1974.

**ТАТАРСТАННЫ́Ң ФӘННИ́-ТЕ́ХНИК МӘГЪЛҮМА́Т ҮЗӘГЕ́** (ФТМҮ), ТАССР ХХСның 1957 ел 17 декабрь күрсәтмәсе б-н РСФСРның Татар икътисади адм. районы ХХС карамагындагы Үзәк техник мәгълүмат бюросы буларак оеша. 1960–80 елларда исеме һәм адм. бәйлелеге күп тапкырлар үзгәрә. 1992 дән ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы ДУП, фәнни-методик җитәкчелек ТР ФА тарафыннан гамәлгә ашырыла. 2004 тән хәзерге исемдә. Оешманың төп бурычы — ТР пр-тиеләре һәм оешмаларының фәнни, инновацион һәм җитештерү эшчәнлеген фәнни-техник һәм мәгълүмати ресурслар б-н тәэмин итү. ФТМҮ карамагында — патент кәгазьләрен саклау һәм исәпкә алу, интеллектуаль милекне саклау, хөкүмәтнең дәүләт органнары сораулары буенча эксперт һәм аналитик вазифасын башкару. Үзәк составында фәнни-техник мәгълүмат, технологияләр коммерцияләштерү, техн. документлар бүлекләре бар. ФТМҮ «Татарстанның интеллектуаль потенциалы» бердәм мәгълүмат банкын булдыруга хезмәт итә.

ФТМҮнең директорлары: В.А.Пронин (1957–92), М.Я.Шәрәфетдинов (1992–2001), А.Э.Ибраһимов (2001–08), В.П.Горячкин (2008–2012), А.Т.Насыйров (2012 дән).

**«ТАТАРСТРОЙМАТЕРИА́ЛЫ»**, к. *Сәнәгый төзелеш.*

**«ТАТА́РТ»**, беренче Бөтентатар сынлы сәнгать күргәзмәсе, 1991 елның 31 маеннан 10 июленә кадәр СССР халыкларының дәүләт этнография музеенда эшли (хәзер С.-Петербургның Россия этнография музее); әлеге вакыйгага багышланган чаралар ш.у. Юсуповлар сараенда үткәрелә. Күргәзмә хәзерге заман татар сәнгате фестивале кысаларында Казан, Уфа, С.-Петербург, Мәскәү, Ташкент, Алма-Ата, Әстерхан, Симферополь һ.б. шәһәрләрдәге әйдәп баручы сынлы сәнгать осталарын ачыклау максатында оештырыла. Хәзерге заман нәкыше, графикасы, скульптурасы һәм гамәли-бизәлеш сәнгате б-н бергәттән (РФ өлкәләреннән һәм респ-каларыннан, БДБ төбәкләреннән 140 рәссамның 400 артык хезмәте), Россия этнография музее тупланмаларыннан татар гамәли-бизәлеш сәнгатенең тиңдәшсез әсәрләре тәкъдим ителә. Ретроспектив өлешен Б.И.Урманче, Ф.Г.Әминов, Ә.Х.Ситдыйкованың нәкышь картиналары тәшкил итә. Күргәзмә иҗат мәктәпләренең, стильләренең (реализмнан постмодернизмга кадәр) һәм авангард агымнарының (экспрессионизм, неопримитивизм һ.б.) күптөрлелеген һәм бер үк вакытта рәссамнарның милли традицияләргә тугрылыгын ача. Казанда күргәзмә 1991 нең 23 августыннан 30 сентябренә кадәр эшли. Әсәрләрнең бер өлешен рәссамнар «Казан» милли мәдәният үзәгенә бүләк итәләр. ТР Рәссамнар берлеге 2007 нең ноябрендә Бөтендөнья татар конгрессының 15 еллыгына шул исемдәге күргәзмә оештыра. Ул Мәскәүнең Кырым валындагы Үзәк рәссамнар йорты залларында, шул ук елның декабрендә Казанда, ТР Рәссамнар берлегенең Күргәзмәләр залында тәкъдим ителә.


«Татарт» күргәзмәсе эмблемасы.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ТАТА́ХРР**, Революцион Россия рәссамнар ассоциациясенең Татарстан бүлеге, 1923 елның февралендә ТАССР Халык мәгарифе

комис-тының Академик үзәге каршында П.А.Радимов һәм А.В.Григорьев башлангычы б-н оештырыла (алар 1922 дә Мәскәүдә Россия Ассоциациясен төзүдә дә катнашалар). 1928 дән ТатАХР исемендә (Татарстан рев-ция рәссамнары ассоциациясе), 1931 нең декабренә кадәр гамәлдә була. Т.ның төп эшчәнлеге соңгы чор күчмә күргәзмә рәссамнары рухындагы рус реалистик мәктәбе традицияләренә тугрылыклы станлы нәкышь рәссамнарын берләштерүгә юнәлдерелә. 1923 тә беренче күргәзмә каталогында берләшмәнең Декларациясе басыла, анда: «Безнең гражданлык бурычыбыз тарихның бөек мизгелен революцион омтылышта гәүдәләндерүдә. Без халыкара пролетариат каршында революциянең абруен төшерүче абстракт уйдырмаларны түгел, ә вакыйгаларның чын картинасын бирәчәкбез», — диелә; шуның нигезендә рәссамнар, төзелешләргә, пр-тиеләргә, колхозлар һәм коммуналарга барып, натурадан этюдлар иҗат итәләр. Икенче юнәлешне татар, мари, чуаш һ.б. Идел буе халыкларының көнкүреше һәм мәдәниятенең этнографик үзенчәлекләрен сурәтләү тәшкил итә. Берләшмә әгъзаларының картиналары системалы рәвештә киң тамашачыга күрсәтелә (ун күргәзмә оештырыла). 1920 елларның 2 нче яртысында Т. әгъзаларының саны 60 ка җитә. П.М.Байбарышев, П.П.Беньков, Д.Г.Булат, П.Ф.Григорьев, И.И.Князьков, А.М.Кокорев, Г.Г.Медведев, И.А.Никитин, П.Т.Сперанский, Н.М.Сокольский, В.К.Тимофеев, Е.К.Частихина иң зур рәссамнар санала, алга таба аларның күбесе ТАССР совет рәссамнары берлегенә керә (к. *Татарстан Республикасының Рәссамнар берлеге*). Рәисләр: Н.П.Христенко (1923), А.К.Лукоянов (1924), В.К.Тимофеев (1924–25), И.А.Никитин (1926–31).

*Әд.:* Червонная С.М. Искусство Советской Татарии. Живопись. Скульптура. Графика. М., 1978; Выставка искусства Татарии 1920–1930-х годов: Каталог. К., 1990.

**ТАТБЫТПРОМСОЮ́З**, к. *Татарстан көнкүреш кәсепчелеге берлеге.*

**ТАТГИ́З**, к. *Татарстан китап нәшрияты.*

**ТАТГОСИЗДА́Т**, к. *Татарстан китап нәшрияты.*

**«ТАТГРАЖДАНПРОЕ́КТ»**, к. *«Татинвестгражданпроект».*

**ТАТИЗДА́Т**, к. *Татарстан китап нәшрияты.*

**«ТАТИНВЕСТБА́НК»,** РФ банк системасының икенче дәрәҗәдәге коммерция акц. банкы. 1992 елда СССР дәүләт банкы Татарстан респ-ка конторасының Вахитов р-ны бүлеге (1940 та ачыла) җирлегендә оеша. 1992 дән АҖ. 2014 тә «Инвестиция кооператив банкы» («ИК-Банк») дип үзгәртелә. Банкның төп акционерлары — 12 юридик зат. «Т.»ның устав капиталындагы өлешләре 20% тан ким булмаган иң эре оештыручылары һәм акционерлары: «Итил» иминият компаниясе АҖ, «БИТ» ҖЧҖ, «Алмаз» җитештерү кооперативы; оештыручылар арасында — «Химимпорт» АҖ, «Казгражданпроект» институты» АҖ, Казан архит-ра-төзелеш ун-ты һ.б. Соңгы елларда «Урал транспорт компаниясе» ҖЧҖ һәм «Финист» предприятиесе» кебек акционерлар килү «Т.»ның ил икътисадына катнашу мөмкинлекләрен сизелерлек киңәйтә.

«Т.» кредитлар бирү, комплекслы валюта хезмәте күрсәтү, кертемнәр һәм депозитлар кабул итү, исәп-хисап-касса операцияләре, кыйммәтле кәгазьләр б-н операцияләр һ.б. кебек традицион банк операцияләренең һәммәсен дә башкара. Банк эшенең өстенлекле юнәлеше — икътисадның реаль секторына: сәнәгать һәм сәүдә пр-тиеләренә, кече һәм урта эшмәкәрлеккә (кредитларның төп өлеше шуларга бирелә) хезмәт күрсәтү. «Т.» берничә тапкыр халыкара һәм Россия бүләкләренә лаек була. 2005 тә Халыкара сыйфат һәм маркетинг академиясе һәм Югары сыйфатлы продукция ассоциациясе үткәргән конкурс нәтиҗәләре буенча халыкара «Европа сыйфаты» алтын медале» бүләгенең лауреаты була. 2006 да «Т.» «Идел буе федераль округының иң көчле үсүче банкы» исемен ала, 2008 дә яңадан әлеге еллык бүләкнең лауреаты була һәм «Төбәкнең иң көчле үсүче банкы» исемен яулый.

Кредит сәясәте, пр-тие һәм оешмалар арасындагы исәп-хисап эшләренә хезмәт күрсәтүдә җитезлеге б-н «Т.» аларның яхшы эшләүләренә этәргеч бирә, ш.у. Россия товар җитештерүчеләренә булышлык итә, ТР һәм РФ икътисады үсешенә нәтиҗәлерәк ярдәм итү өчен зарур яңа эш урыннары булдыруны тизләтә.


«Т.»ның алга таба үсешенең төп юнәлешләре: клиентларга хезмәт күрсәтүнең сыйфатын күтәрү һәм банк хезмәте күрсәтүне киңәйтү, үз капиталын арттыру, даими рәвештә иң яңа технологияләр кертү һәм банк эшчәнлегендә яңа алдынгы юнәлешләрне үстерү. 2006 ның 1 гыйнварына «Т.»ның үз капиталы — 111,2, 2008 гә — 164,1, 2015 кә 293,7 млн. сум тәшкил итә.

*Р.К.Мәҗитова, И.К.Харисов.*

**«ТАТИНВЕСТГРАЖДАНПРОЕ́КТ»**, дәүләт унитар пр-тиесе. Барлыгы 396 кеше эшли (2010). 1992 елда Казанда «Татгражданпроект» проектлау ин-ты җирлегендә оештырыла (1934 елда «Татпланпроект» проектлау-планлаштыру конторасы буларак нигез салына). Чаллы, Түбән Кама, Яшел Үзән, Чистай, Алабуга шәһәрләрендә архит-ра-планлаштыру остаханәләре бар. Эшчәнлегенең төп юнәлешләре: шәһәрләр һәм посёлоклар, микрорайоннар һәм кварталлар, җәмәгать үзәкләре һәм шәһәр яны зоналары төзелешләрен; уникаль биналар һәм корылмаларны (хөкүмәт һәм офис-сәүдә биналары, спорт-тамаша корылмалары, храмнар, мәгариф, сәламәтлек саклау һәм мәдәният учреждениеләре), транспорт инфраструктурасы объектларын (күперләр, вокзаллар, станцияләр, юл үткәргечләр һ.б.), коммуналь объектларны (ягу биналары, су алгычлар, чистарту һ.б. корылмалар), табигатьне саклау комплексларын (урман парклары, ял һәм туристлык базалары, бакчалар һ.б.) проектлаштыру; офислар һәм сәүдә комплекслары, торак йортлар һәм коттеджлар архит-расы һәм дизайны; архит-ра истәлекләрен реставрацияләү һ.б. «Т.» максатчан федераль программаларны, ш.и. «Казан шәһәренең тарихи үзәген саклау һәм үстерү», «Россия гражданнарына — һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак» программаларын гамәлгә ашыра, ТРдагы барлык шәһәрләр һәм район үзәкләренең ген. планнарын эшли.

Казанда «Т.» проектлары буенча Үзәк стадион, цирк, ТР Рәссамнар берлегенең Күргәзмәләр залы төзелә, Казанның 1000 еллыгына Колшәриф мәчете, Татар гуманитар-пед. ун-тының төп бинасы (хәзер КФУ бинасы) корыла, Казанның мәңгелыгы паркы ачыла, Казан Кремле, Үзәк стадион, Петропавел соборы, элеккеге Мария гимназиясе бинасы һ.б. архит-ра ансамбльләре реконструкцияләнә. Универсиада–2013 кә 10 мең кешегә исәпләнгән Универсиада авылы һәм тиңдәшсез спорт корылмалары: Су спорты төрләре сарае, Теннис академиясе, стадионнар һ.б. төзелә. Пр-тие тарафыннан эшләнгән күп кенә проектлар һәм төзелгән объектлар СССР МС бүләге (1971), ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (1981), РФ Дәүләт бүләге (2004) б-н билгеләп үтелә. Ген. директоры — А.А.Хөснетдинов (2010 нан).

**ТАТИ́ЩЕВ** Василий Никитич (19.4.1686, Псков ш. янында — 15.7.1750, Мәскәү губ., Дмитровский өязе Болдино а.), дәүләт эшлеклесе, тарихчы, яшерен советник (1737). Дворяннар нәселеннән. Мәскәүдә Инженерлар һәм артиллерия мәктәпләрен тәмамлый. 1700–21 еллардагы Төньяк сугышында, 1711 дәге Прут явында катнаша. Пётр I нең хәрби һәм дипломатик йөкләмәләрен башкара. 1720–22, 1734–37 дә Уралда казна з-длары б-н идарә итә, Екатеринбург шәһәренә нигез сала. 1724–27 дә Швециядә. 1727–33 тә Мәскәүдә акча сугу конторасы әгъзасы. 1720, 1734, 1737 елларның җәендә Казанга килеп китә; Кремль, арсенал, постау мануфактурасы торышы турында кыскача күзәтү әзерли. 1735 һәм 1737 дә, Казан губернасы турында мәгълүмат туплауда һәм Идел буе, Себер ландкарталарын төзүдә ярдәм сорап, Казан губернаторлары П.И.Мусин-Пушкинга һәм С.Д.Голицынга мөрәҗәгать итә; шул максат б-н Казанга М.С.Пестриков җитәкчелегендә геодезистлар җибәрә (1739 да алар «Казанны тасвирлау» («Описание Казани») хезмәтен тәкъдим итәләр). Оренбург (1737–39) һәм Калмык (1741–45) комиссияләре башлыгы, бер үк вакытта, 1741–45 тә, Әстерхан губернаторы. Башкортлар күтәрелешен бастыруны җитәкли, яңа урында Оренбург шәһәрен һәм Оренбург ныгытылган линиясе ныгытмалары төзи, Башкортстанда берничә казна з-ды ача. 1745 нең ахырында Казан губернасының Тәтеш авылында, 1746 дан Болдино авылында яши. Т. рус телендә шәрехләүләр б-н тарихи чыганакларның беренче басмасын әзерли, Россиядә этнография, тарихи геогр., чыганакларны өйрәнү гыйлеме үсешенә нигез сала. Күпсанлы рус һәм чит ил чыганакларына нигезләнеп, «Иң борынгы заманнардан Россия тарихы» («История Российская с самых древнейших времён», 1–5 кит., М., 1768–1848) — Ватан тарихына багышланган гомумиләштерүче беренче фәнни хезмәт яза. Т. гражданнар тарихын башка фәннәрдән аерып карый һәм рационалистик


В.Н.Татищев.

принципларга нигезләнеп теория мәсьәләләрен һәм тарихны танып белү алымнарын ачыклый. Беренче тапкыр рус историографиясендә җәмгыять үсешендәге закончалыкларны табарга, дәүләт хакимияте барлыкка килүнең сәбәпләрен дәлилләргә омтылыш ясый. Тарихи процессны «аң-белем» үсеше б-н бәйләп, Т. Россия тарихын дәверләргә бүлә; ул Россия тарихының гомуми концепциясенә самодержавие тарихын кертә. Текст күпсанлы елъязмалардан һ.б. чыганаклардан, ш.и. Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, татар ханлыклары, Россиянең шәрекъ халыклары б-н дәүләтара мөнәсәбәтләре, Рус дәүләтенә Идел буе, Урал, Себер дәүләтләре кушылу тарихы турындагы чыганаклардан җыелган фәнни һәм текстологик шәрехләүләре булган хәбәрләрдән тора. Т.ның «Иң борынгы заманнардан Россия тарихы» тупланган мәгълүматның күплеге, бәян ителгән вакыйгаларны фәлсәфи һәм сәяси яктырту ягыннан фундаменталь хезмәт булу б-н бергә 18 йөз историографиясе һәм мәдәниятенең кыйммәтле ядкәрен тәшкил итә. Т. «Россиянең тарихи, географик, сәяси һәм гражданнар лексиконы» («Лексикон Российский исторический, географический, политический и гражданский», ч. 1–3, СПб., 1793) исемле беренче рус энциклопедик сүзлеген төзи. «Рус шляхтасының дәүләт идарәсе турында ирекле һәм килешенүле фикерләре һәм уйлары» («Произвольное и согласное рассуждение и мнение собравшегося шляхетства русского о правлении государственном», 1730; нәшер ителә: М., 1859.), «Улыма үгет-нәсихәт» («Духовная моему сыну», 1733; нәшер ителә: СПб., 1773; 2 нче басма — 1885), «Ике дусның фән һәм училищеләрнең файдасы турында сөйләшүе» («Разговор двух приятелей о пользе наук и училищ», 1733–36; нәшер ителә М., 1887), «Кабинетка башкорт чуалышларының сәбәпләре һәм башкортлар белән идарә итүне яхшырту чаралары турында хәбәр итү» («Представление в Кабинет о причинах башкирских волнений и о мерах для улучшения управления башкирами», 1737; нәшер ителә: М.–Л., 1949), «Югары һәм түбән дәүләт һәм земство хөкүмәтләренең җибәрелгән расписаниесе турында искәртмә» («Напоминание на присланное расписание высоких и нижних государственных и земских правительств», 1739–40; нәшер ителә: М., 1859), «Халык исәбен алу турында фикерләр» («Рассуждение о ревизии поголовной», 1742; нәшер ителә: М., 1861) хезмәтләрендә дәүләт һәм җирле реформаларны, фән һәм мәгариф үсешен яклаучы буларак чыгыш ясый. Т. — ш.у. Россия географиясенә багышланган әсәрләр авторы.

Х е з м.: Избранные труды по географии России. М., 1950, Записки. Письма. 1717–1750 гг. М., 1990.

*Әд.:* П о п о в Н.А. В.Н.Татищев и его время: Эпизод из истории государственной, общественной и частной жизни в России первой половины прошедшего столетия. М., 1861; К у з ь м и н А.Г. Татищев. М., 1987; Ш а к и н к о И.М. В.Н.Татищев. М., 1987. *Е.Б.Долгов.*

**ТАТИ́ЩЕВ** Иван Андреевич (1740–1789, Казан), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, генерал-майор (1780). Дворяннар нәселеннән. 1757 елдан хәрби хезмәттә. 1783 тән Казан наместниклыгы идарәчесе. Т. дәверендә Казан губернасы гербы раслана (1785); Казанда дары з-ды (1786), әсасый халык уч-щесе (1786), гомуми һәм алты гласныйлы шәһәр думасы ачыла (1789); Беренче ир балалар гимназиясе ябыла (1788).

*Әд.:* Д о л г о р у к о в П.В. Российская родословная книга. СПб., 1855. Ч. 2; Т а т и щ е в С.С. Род Татищевых. 1400–1900: Ист.-генеал. исслед. СПб., 1900. *Е.Б.Долгов.*

**«ТАТКИНО́»**, кино төшерү һәм фильмнарны прокатка бирү б-н шөгыльләнгән җитештерү-иҗат берләшмәсе. ТАССР Мәгариф халык комис-тының Госкино б-н төзелгән килешүе нигезендә кабул ителгән 1924 ел 13 февраль карары б-н төзелә. Хосусый капитал катнашында акц. җәмгыяте буларак оеша, 1924 нең 1 октябреннән дәүләт учреждениесе. Ул Казандагы 8 кинотеатрны («Электра», «Унион», «Олимп», «Палас», «Адмиралтейский», «Пассаж», «Народный», «Красная Звезда»), ш.у. респ-каның авыл кантоннарында аена 20 фильмнан да ким булмаган санда кино күрсәтүче күчмә кино челтәрләрен (30 дан артык) берләштерә. 1924 нең сентябрендә Казанда «Чаткы» кинотеатры ачыла, анда татарча титрлар б-н фильмнар бара (беренчеләрдән булып «Потёмкин» броненосецы» («Броненосец «Потёмкин»), «Мөселман кызы» («Мусульманка») фильмнары, Д.Вертовның «Киноправда» кинож-лы күрсәтелә). Кинотеатрлар һәм күчмә киноларны даими рәвештә фильмнар б-н тәэмин итү өчен, булачак Таткинопрокатка нигез салган кино фонды төзелә башлый; яңа фильмнар булдыру өчен, «Т.»ның Мәскәүдә штатта торучы вәкиле була. Киномеханиклар әзерләү өчен махсус курслар оештырыла, кинотеатрлар эшчәнлеге турында хисап тоту системасы эшләнә. Бер үк вакытта үз фильмнарын җитештерүне һәм үз киноларын төшерүне оештыру эше бара. 1924 нең кышында Мәскәүдә — В.И.Ленинны җирләү эпизоды, 1924 нең җәендә Беренче бөтендөнья сугышы башлану датасы уңаеннан Казанда узган массакүләм театральләштерелгән тамаша («Беренче империалистик сугыш инсценировкалары» — «Инсценировки Первой империалистической войны») төшерелә. 1924 нең көзендә кыска метражлы хроникаль фильмнар эшләнә: «Иптәш Луначарскийның Казанга килүе» («Приезд товарища Луначарского в Казань»), «Казанда Октябрь бәйрәме» («Октябрьская годовщина в Казани»), алар «Электра» һәм «Унион» кинотеатрларында күрсәтелә. 1926 ның җәендә кинооператор К.Ф.Мотков беренче тапкыр *Сабан туе* бәйрәмен төшерә. Кинооператорлар әзерләү максатыннан «Т.», стипендия б-н тәэмин итеп, 7 кешене Мәскәүгә кинематография техникумына командировкага җибәрә (стипендия алучылар арасында — К.Ф.Мотков, К.Х.Поздняков, Ә.Г.Мәҗитов, Ильясов, Гобәйдуллина). «Т.»да ш.у. З.В.Баязитский, З.З.Сабитов та эшли. 1927 дә операторлар К.Х.Поздняков һәм Ә.Г.Мәҗитов реж. Ю.В.Таричның «Булат батыр» нәфис фильмын төшерүдә катнашалар. «Т.» 1927 дә ТАССР ХКС тарафыннан оешкан Татарстан тамаша пр-тиеләре идарәсе составына керә, ул 1928 дә ябылганнан соң, кино җитештерү эше «*Востоккино*» АҖ карамагына күчә. *Е.П.Алексеева.*

**ТАТКРАХМАЛПА́ТОКА**, к. *Крахмал-патока җитештерү.*

**ТАТЛЕСПРОМСОЮ́З**, к. *Татарстан агач кисү һәм эшкәртү кәсепчелеге кооперацияләре берлеге.*

**ТАТЛЕ́Ф** (Татарстан сәнгатенең сул фронты), мәдәният эшлеклеләренең иҗат берләшмәсе, 1923 тә, Мәскәү ЛЕФының ф-лы буларак, Казанда нигез салына. Әгъзалары — Казан архит-ра-сәнгать ин-ты укытучылары һәм студентлары төркеме (к. *Казан сәнгать училищесе*): А.Н.Кашаев (укытучы), К.К.Чеботарёв, А.Г.Платунова, М.В.Барашов, А.Н.Коробкова, Ф.П.Гаврилов, С.П.Козлов, Б.М.Столбов, *КЭМСТ* труппасы актёрлары. Т. б-н параллель татар сул фронты — СулФ төзелә, аны оештыручыларның берсе — рәссам Ф.Ш.Таһиров, СулФ әгъзаларына Татар дәүләт театры актёрлары Ф.Сәлләви, Ә.Г.Мәҗитов, С.Я.Вәлиев-Сульва керә, язучылардан нигез салучыларның берсе — Г.Ж.Толымбайский, аңа Г.Кутуй, К.Нәҗми, Н.Арслан килеп кушыла. Т. һәм СулФ рәссамнары сәнгатьтә академик юнәлешне кире кагалар, реалистик театр б-н бергә нәкышьнең станлы формаларында реформа өчен чыгыш ясыйлар, аларның иҗаты «сәнәгать сәнгате» идеяләре, дизайн, театр декорациясе сәнгате, монументаль нәкышь, агитация плакаты, сәнәгать һәм китап графикасы, фотомонтаж һ.б. үсеше б-н бәйле була. Т.ның 2 күргәзмәсе — «Казан, алга!» (1924) һәм «ЛЕФның лаборатор-җитештерү хезмәтләреннән 2 нче сынлы сәнгать күргәзмәсе» (1925) оештырыла. 1926 да берләшмәнең эшчәнлеге туктала.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Искусство Советской Татарии. Живопись, скульптура, графика. М., 1978; Выставка искусства Татарии 1920–1930-х годов: Каталог. К., 1990.

**ТАТЛЫ́ ТАМЫ́Р**, г а м б ә р и я ч ә ч ә г е (Scorzonera), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә икеельлык үләнчел үсемлекләр һәм ярымкуаклар. 170 кә якын төре билгеле, Евразиядә таралганнар. ТР терр-ясендә 5 төре билгеле. Кызыл Т.т. (S. purpurea) — күбесенчә көньяк районнарда, Кырым Т.т.ы (S. taurica), Австрия Т.т.ы (S. austriaca), вак чәчәкле Т.т. (S. parviflora), туры Т.т. (S. stricta) Кама аръягында очрый. Далаланган тау битләрендә, карбонатлы ачылмаларда үсә. 10 нан 120 *см* га кадәр биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамыры үзәк, кара көрән яки кара төстә. Яфраклары чиратлашкан, бөтен читле, каурыйсыман теленмә. Чәчәкләре телчекле сары яки алсу төстә берле кәрзиннәрдә. Җимеше — төкчәле яки шома орлыклар. Тамырларында җиңел үзләштерелүче шикәр, азотлы матдәләр, ви-

таминнар, микроэлементлар бар. Яшь яфракларыннан салат ясыйлар. Баллы, декоратив үсемлек. 4 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ТАТМАСЛОСОЮ́З**, к. *Татарстан сөт кооперациясе берлеге.*

**ТАТМЕ́ДИА**, ТРдагы медиакомпания, ААҖ. 2003 елда оештырыла. Татарстан Респ-касы Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгы карамагында. Т. составына 88 ф-л: 99 газета, 17 журнал, 23 телекомпания, 13 радиостанция, мәгълүмат агентлыгы, электрон газета (93 интернет-сайт), «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы һ.б. керә (2014). Эшчәнлегенең төп юнәлешләре: массакүләм мәгълүмат чаралары продукциясен (газеталар, журналлар, телевидение һәм радио программалары, фильмнар) җитештерү һәм тарату; реклама эшчәнлеге; ТРның массакүләм мәгълүмат чаралары аша халыкка яңа мәгълүматлар җиткерү мөмкинлеге бирү; пресс-конференцияләр оештыру һәм үткәрү. Т. ф-ллары ТРның барлык шәһәрләрендә дә бар. Генераль директорлары — Ф.И.Шаһиәхмәтов (2013–15), 2015 тән — А.Кузьмин.

**ТАТМЕТАЛЛПРОМСОЮ́З**, к. *Татарстан металл эшкәртү кәсепчелеге кооперативлары берлеге.*

**«ТАТМЯСОПРО́М»**, к. *Ит эшкәртү сәнәгате.*

**ТАТНЕФТЕГАЗРАЗВЕ́ДКА**, к. *Татарстан геологик разведка идарәсе.*

**«ТАТНЕФТЕГЕОФИ́ЗИКА»**, к. «*ТНГ-Групп*».

**«ТАТНЕ́ФТЬ»**, составына нефть-газ чыгару идарәләре, нефть эшкәртү һәм нефть химиясе пр-тиеләре, сервис хезмәте һәм нефтьне, нефть-газ эшкәртү, нефть химиясе продуктларын сату пр-тиеләре кергән холдинг-структура. РФнең иң зур нефть компанияләренең берсе; ул ш.у. банк һәм иминиятләштерү эшчәнлегендә, ТРның күп кенә әйдәп баручы нефть химиясе пр-тиеләре б-н идарә итүдә катнаша. Нефть чыгару күләме буенча илдә 6 нчы урынны алып тора — елына 26,23 млн. *т* (700 млн. *м*³ газ): 82 нефть чыганагында нефть һәм газ чыгара (шуларның икесе — Әшәлче һәм Мордва-Кармала чыганаклары тәҗрибә-сәнәгать эшкәртүе дәрәҗәсендә). 2014 тә Әшәлче чыганагында 236,9 *т* үзле нефть чыгарыла. Респ-када нефть чыгарыла башлаганнан бирле табылган нефтьнең төп өлеше «Т.»кә туры килә (2007 дә 3 млрд. *т*). Компания ТРда гына түгел, РФ терр-ясендә, якын һәм ерак чит илләрдә дә бизнес-проектларын үстерә бара. Агымдагы нефть чыгаруның төп өлеше 6 эре чыганакка — Ромашкино, Яңа Елховой, Баулы, Сабанчы, Беренче май, Бондюг чыганакларына карый.

Холдинг эшчәнлегендә иң өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып нефть чыгаруның гамәлдәге алымнарын камилләштерү һәм яңаларын эшләү тора. Чыгарылган нефтьнең 45% ы катламнарның нефть бирүчәнлеген күтәрә торган заманча алымнар куллану һәм яңа технологияләр кертү хисабына табыла. 2000 елларда разведка һәм файдалану өчен бораулау күләмнәре 2 тапкыр арттырыла. Алдынгы фәнни технологияләрне үстерү, ш.у. югары технологияле җитештерү күләмен һәм төрләрен күпләп кертү нәтиҗәсендә компаниянең дәрәҗәсе күтәрелә һәм үз тармагында көндәшлеккә сәләте арта бара. 2009 да 16 яңа нефть чыганагы (ш.и. чит илләрдә) ачыла.

«Т.»нең тарихы 1949 дан башлана — Бөгелмә шәһәрендә Шөгер һәм Баулы эреләндерелгән нефть промыселлары җирлегендә «Татнефть» тресты, «Туймазынефть» трестының 3 нче бораулау конторасы оештырыла, Ромашкино нефть промыселы һәм төзү-монтаж идарәсе төзелә. Шөгер, Баулы һәм Ромашкино нефть чыгнакларын эшкәртү б-н нефтьне күпләп чыгару башлана. 1950 дә СССР МСның «Татарстан АССРда нефть чыгару үсешен тизләтү чаралары турында»гы карары нигезендә «Т.» берләшмәсе оештырыла, аңа «*Баулынефть*», «Бөгелмәнефть» (соңрак «*Лениногорскнефть*»), «Татбурнефть» трестлары, «Татнефтепромстрой» төзү-монтаж тресты, «Татнефтепроект» проектлау конторасы кертелә. 1952 дә берләшмәдә «*Әлмәтнефть*», «Әлмәтбурнефть», «Татнефтегеофизика», «Таттехснабнефть», «Татнефтепроводстрой», «Ромашкиннефтестрой», «Бөгелмәнефтестрой» трестлары төзелә. 1950 еллар ахырына «Т.»тә эшләүчеләрнең гомуми саны 7635 кеше булган 40 тан артык пр-тие һәм оешма эшли.

1956–70 тә «Т.»нең яңа бүлекчәләре төзелә: ТатНИИ, И.М.Губкин исем. Мәскәү нефть ин-тының консультатив пунктлары (хәзер Әлмәт нефть ин-ты), Алабуга эреләндерелгән нефть промыселы, «*Азнакайнефть*», «Актүбәнефть», «*Җәлилнефть*», «*Елховнефть*», «*Иркеннефть*», «*Прикамнефть*», «Сөләйнефть», «*Ямашнефть*» нефть промыселы идарәләре (1970 тә барлык идарәләр НГДУ итеп үзгәртелә), «Татнефтегаз» тресты, Катламнарда басымны тоту өчен технол. сыекча әзерләү идарәсе, Лениногорск катламнарның нефть бирүчәнлеген күтәрү һәм скважиналарга капиталь ремонт ясау идарәсе һ.б.

1943–55 тә «Т.»тә 33,3 млн. *т* нефть чыгарыла, тармакта беренче тапкыр алдынгы фәнни-техник һәм җитештерүне оештыру яңалыклары, ш.и. бораулау вышкаларын зур блоклы нигезләргә (авыр йөк ташу лафетлары б-н күчереләләр) салу алымы киң кулланыла. Вышкалар төзүнең әлеге индустриаль ысулына күчү нәтиҗәсендә бораулау җайланмасын монтажлау вакыты 26 көннән (1953) 6 көнгә кадәр (1958) кыскара. 1959 да илдә беренче булып тәүлегенә 100 мең *т* нефть чыгаруга ирешелә.



Беренче нефть эзләү скважинасы. 1940 еллар.

Нефть чыгаруны тизләнешле үстерү программасын кабул итү (1959–65) б-н чыганакларны эшкәртү системасы яңартыла. *Ромашкино чыганагыннан* нефть чыгаруда СССРда һәм дөньяда беренче тапкыр контур эченә су тутыру алымы эшләнә һәм үзләштерелә, *Яңа Елховой чыганагында* су сайлап алынган һәм аерым урыннарга тутырыла. Контурның тышына һәм эченә су тутыру алымнары нефть чыгару күләмен кискен арттыру мөмкинлеге бирә. 1960 еллар ахырына СССР нефть сәнәгатендә беренче тапкыр нефть бирүчәнлекне арттыру максатында продуктив катламнарга зур күләмнәрдә күкерт к-тасы кертүнең технол. схемасы эшләнә һәм гамәлгә ашырыла.

1957 дә «Т.» чыганакларындагы иярчен газны эшкәртүгә корылган Миңлебай газ-бензин з-дының 1 нче чираты сафка кертелә. 1960 та Әлмәт шәһәре янына «Дуслык» нефть үткәргеченең төп корылмалары урнаштырыла һәм Татарстан нефте Көнчыгыш Европа илләренә җибәрелә башлый.

1970 елларда фәнни-техник алгарышны тизләтү максатыннан ТатНИИ, «Татнефтепроект» ин-тлары ТатНИПИнефть ин-тына берләштерелә. 1970 тә еллык нефть чыгару күләме буенча илдә иң зур дәрәҗәгә ирешелә (100 млн. *т* дан артык), һәм ул 1976 га кадәр саклана (1975 тә 103,7 млн. *т*). 1971 дә «Т.» беренче млрд. *т* нефть чыгара. 1973 тә тармакта беренче «ТатАИСнефть» идарәсе төзелә, ул берләшмәнең автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын эшләтә һәм аларга хезмәт күрсәтә, катламнарның нефть бирүчәнлеген күтәрү һәм скважиналарга капиталь ремонт ясау эшләрен алып бара. Тармакта беренче булып «Әлмәтнефть» НГДУда нефть промыселлары комплексы автоматлаштырыла һәм телемеханикалаштырыла; катламнан оптималь файдалану технологиясе нигезләре актив кертелә башлый. Нәтиҗәдә, табыла торган углеводородларның сулылыгын киметү мөмкин була, чыгарылган сыеклык күләме 2,8 тапкыр кими.

1970 елларда скважиналардан файдалану фонды структурасы тамырдан үзгәртелә. Нефтьнең 90% тан артыгы механикалаштырылган юл б-н чыгарыла (1966 да 28% тан артмый). Төзәтү эшләренең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, скважиналардан файдалануның ремонтара вакытын озайтуга юнәлтелгән күп кенә чаралар башкарыла.

1976 да нефть чыгару (Әлмәт, Азнакай) һәм бораулау (Лениногорск) җайланмаларын, батырылма электр җиһазларын (Әлмәт) төзәтү буенча үзәк хезмәт күрсәтү базалары оештырыла. 1979 да «*Нурлатнефть*» НГДУ оештырыла. 1977 дә «Т.»кә В.Д.*Шашин* исеме бирелә.

1980 еллардан башлап, Татарстан нефтьчеләре Көнбатыш Себер нефть чыганакларын үзләштерүгә зур өлеш кертәләр. 1981 дә, респ-ка нефть чыганакларын үзләштерә башлаганнан алып, «Т.» икенче млрд. *т* нефть чыгара. Бу чорда, ТатНИПИнефть эшкәртмәләренә нигезләнеп, илдә беренче тапкыр битумнарны скважиналы ысуллар б-н чыгаруның тәҗрибә-сәнәгый эшләре башланып китә (беренче 4 мең *т* битум алына).

1980–93 тә, төп ике — Ромашкино һәм Яңа Елховой чыганакларының күп өлеше файдаланылу аркасында, «Т.»нең нефть чыгару күләме кими. 1994 тә 23,6 млн. *т* нефть чыгарыла. Күләмнең түбәнәю тизлеге елына 3–4 млн. *т* тәшкил итә. Нефть чыгаруның кимүен илдәге икътисади кризис һәм дәүләт инвестицияләренең азаюы тагын да көчәйтә. Бу хәлне туктату максатында концепция эшләнә һәм ул нефть чыгару күләмен геол.-техник чараларны киңәйтү хисабына тотрыклыландыруны күздә тота. 1995 тә нефть чыгаруга салымнарны стимуллау кулланыла; рентабельсез скважиналардан һәм яңа чыганаклардан нефть бирүчәнлекне күтәрүнең яңа алымнарын кулланып чыгарган нефть өчен өстенлекле түләү кертелә. Шул вакыттан башлап, нефть чыгаруда тотрыклылык күзәтелә (1997 дә 24,6 млн. *т*, ягъни РФдә чыгарылган нефтьнең 8%ы). Катламнарның нефть бирүчәнлеген күтәрү өчен, икенчел яки өченчел технологияләр кулланыла башлый (ш.и. гидродинамик, геол.-физик, химик, җылылык, газ, микробиологик һ.б.).

1994 тә «Т.» ҖБ АҖ итеп үзгәртелә. Аның составына 139 структур бүлекчә (ш.и. 25 а.х., 11 торак-хуҗалык), ш.у. җитештерүгә карамаган төп фондлар (100 дән артык мәктәпкәчә учреждениеләр, мәдәният, спорт сарайлары, 3 мең *км* тирәсе автомобиль юллары) керә. Компаниядә эшләүчеләр саны 75 мең кеше була, шуларның 26%ы турыдан-туры нефть чыгару б-н шөгыльләнә. «Т.» илнең нефть чыгару тармагында иң зур АҖләрнең берсенә әверелә. 1990 елларда «Т.» үз акцияләрен халыкара фонд базарларына урнаштыра, Россия һәм халыкара фонд базарларында бара торган барлык процессларда катнаша. 1996 да, җитештерү чыгымнарын киметү һәм төп эшчәнлеккә ныграк туплану максатыннан чыгып, «Т.»тә профильдән үзгә эшчәнлектән арыну һәм структур бүлекчәләр санын кыскарту эшләре башлана.

1990 еллар ахырыннан «Т.» АҖ вертикаль кушылган холдинг компания буларак формалаша. Ул Татарстан нефть химиясе пр-тиеләренең эре пакетларын сатып ала. Нефть химиясе комплексының төп пр-тиесе булып «*Түбәнкамашин*» АҖ тора. РФ һәм Украина (2009 да 620) терр-ясендә үз автозаправка станцияләре челтәрен үстерү программасы уңышлы эшләп килә.

2000 еллар башыннан «Т.» структурасы оптимальләштерелә: газ эшкәртү («Татнефтегазпереработка»), химия («Татнефть-Нефтехим»), яңа терр-яләрдә углеводород чыганакларын эзләү һәм эшкәртү идарәләре төзелә. 2003 тән компания структурасын үзгәртүнең акрынлап «Т.» составыннан профильдән үзгә активларны һәм сервис хезмәтен чыгара баруны күздә тоткан программасы гамәлгә керә.



«Татнефть» АҖ. Административ бина.

«Т.» әйләнә-тирә мохитне саклауга, сәнәгать һәм җитештерү куркынычсызлыгын тәэмин итүгә караган шактый эшләр алып бара. Компания эшчәнлеге терр-ясе өзлексез экологик тикшерелеп тора, нәтиҗәдә, экологик куркынычсызлыкка бәя бирелә, фаразлар ясала һәм тиешле күрсәтмәләр эшләнә. Углеводородларның җиңел фракцияләрен тотып калу технологиясе кертелгән, һәм ул аларның атмосферага чыгарылу күләмен 4 тапкыр киметергә мөмкинлек бирә. Су объектларын саклау чараларын гамәлгә кертү нәтиҗәсендә, компания эшчәнлеге р-ныйндагы төп елгаларда хлоридлар һәм нефть продуктлары санитар нормалардан узмый. 500 дән артык чишмә төзекләндерелә. Торба үткәргечләр системасының ышанычлылыгын арттыру максатында торбаларны коррозиядән саклау технологияләре эшләнгән һәм гамәлгә кертелгән; коррозиягә каршы капламлы торбалар эшләп чыгару җайга салынган һ.б.

1990 еллар башыннан «Т.»нең экспорт сәясәте активлаша. Компания чыгарган нефтьнең яртысы кулланучыларга «Дуслык» нефть үткәргече аша җибәрелә. Әчке базарда продукцияне нефть эшкәртү з-длары ала. 1992 дә төзелгән Тышкы икътисад фирмасы 700 млн. доллардан (АКШ доллары, 2009) артык суммага 700 дән артык экспорт-импорт килешүе төзи. «Т.» 20 дән артык ил, ш.и. АКШ, Канада, ГФР, Бөекбритания, Италия, Франция, Испания б-н экспорт операцияләре алып бара. Гыйрак, Иран, Сирия, Ливия, Вьетнам, Кытай, Согуд Гарәбстаны һ.б. илләрнең нефть компанияләре б-н элемтәләр җайга салынган.



Чылбырлы привод – ТатНИПИнефть галимнәренең һәм «Татнефть» АҖ белгечләренең уртак эшләнмәсе.

2005 тән башлап, «Т.» Самара, Оренбург һәм Ульянов өлкәләрендә, Калмык Респ-касында, Ненец автономияле округында нефть чыганакларын эшкәртү б-н шөгыльләнә. Бу районнар терр-ясендә углеводородларны геологик разведкалау һәм чыгару буенча 9 аффилятив компания төзелә.

АҖнең гамәлдәге эре проектлары — Татарстан терр-ясендәге үтә үзле нефть чыганакларын эшкәртү, нефть эшкәртү һәм нефть химиясе з-дларының иң зур комплексын — Түбән Камадагы «ТАНЕКО» АҖ төзү һ.б. Проектны гамәлгә ашыру 2005 тә башлана. 2011 дә комплексның 1 нче чираты, 2014 башында катнаш гидрокрекинг җайланмасы файдалануга тапшырыла. «Танеко» елына 7 млн. *т* дан артык югары күкертле нефтьнең 96,9% ын эшкәртү, ягулыкның, компонентларның төрле төрләрен, нефть химиясе продукциясен эшләп чыгару өчен чимал (20 ләп төрдә) җитештерү сәләтенә ия. Генерацияләүче активларны ныгыту кысаларында Түбән Кама ГЭСын модернизацияләү дәвам итә. «Т.» энергияне нәтиҗәле тотуга, мәгълүмат технологияләрен үстерүгә һәм социаль үсеш программасына караган проектларны тормышка ашыруда уңышлы эшли. Шәһәрләр һәм бюджет төзүче пр-тие, торак йортлар, мәктәпләр, мәктәпкәчә учреждениеләр, спорт һәм социаль-мәдәни объектлар һ.б. төзелешен финанслый. Компания тарафыннан «Шәфкать», «Рухият», «Одарённые дети — Сәләтле балалар» хәйрия фондлары оештырыла һәм алар уңышлы гына эшләп килә.

Нефть чыгаруны арттыру буенча җидееллык планны уңышлы үтәгәне, нефть чыганакларын эшкәртү алымнарын камилләштерүдә һәм бораулау эшләрен оештыруда ирешкән уңышлары өчен «Т.» ҖБ Ленин ордены (1966) б-н бүләкләнә. «Әлмәтнефть» НГДУ — Ленин ордены (1970), *Миңлебай газ эшкәртү заводы* (1971) һәм Әлмәт бораулау эшләре идарәсе (1981) Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнәләр. «Т.» ш.у. әйләнә-тирәне саклау, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм табигатьтән рациональ файдалану өлкәсендәге халыкара бүләкләргә дә ия. Күпсанлы хезмәткәрләр дәүләт бүләкләренә, ш.и. 22 кеше — Соц. Хезмәт Герое, 1263 кеше — РСФСР, ТАССР, ТРның атказ. нефть-газ сәнәгате хезмәткәре исемнәренә лаек була; 59 кеше — Ленин ордены; 42 кеше — Октябрь Революциясе, 348 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 57 кеше — Халыклар дуслыгы һәм Дуслык, 325 кеше — «Почёт билгесе» һәм Почёт, 236 кеше — 1 нче, 2 нче, 3 нче дәрәҗә Хезмәт даны орденнары, 2 кеше — 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» ордены, 30 кеше — 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен», 5 кеше — «Татарстан Республикасы алдындагы хезмәтләре өчен» орденнары; 30 кеше — 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» орден медале, 3000 нән артык кеше — башка медальләр; 8 кеше — Ленин бүләге, 24 кеше — СССР Дәүләт, 3 кеше — СССР МС, 17 кеше — РФ хөкүмәте бүләкләре, 82 кеше ТР Дәүләт бүләге б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре: А.Т.Шмарёв (1950–56), В.М.Шашин (1956–63), Р.Ш.Мингәрәев (1963–65), А.Ш.Вәлиханов (1965–77), Р.Т.Булгаков (1977–1980), Ә.К.Мөхәммәтҗанов (1980–90), Р.Г.Галиев (1990–99), Ш.Ф.Тәхәветдинов (1999–2013), Н.Ө.Маганов (2013 тән).

Чыг.: Нефть, газ и нефтехимия Татарии: Док. и материалы. К., 1979; История в документах и цифрах: В 2 т. М., 2005.

*Әд.:* Городний В.И. Стратегии формирования и развития крупной корпоративной компании: На примере АО «Татнефть». М., 2005; Книга славы: В 2 т. М., 2005; Открытое акционерное общество «Татнефть»: Годовые отчёты: 1994–2004. М., 2005; Полюшко Ю.Н. Развитие АО «Татнефть» как вертикально-интегрированной компании // Экон. вестн. РТ. 2007. № 2; Чичкова И.В. Анализ инвестиционной привлекательности инновационных проектов ОАО «Татнефть» // Экон. вестн. РТ. 2009. № 1.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ТАТНИИНЕФТЕМА́Ш**, к. *Татарстан нефть машиналары төзү институты.*

**ТАТНИПИНЕ́ФТЬ**, к. *Татарстан нефть фәнни-тикшерену һәм проект институты.*

**«ТАТПЕЧА́ТЬ»**, ТАССРдагы полиграфия пр-тиесе. Гражданнар сугышы елларында шәхси басмаханәләрне конфискацияләү һәм өлешчә хосусыйлаштыруны күздә тоткан *яңа икътисади сәясәт* кертелү нәтиҗәсендә Татарстан XXСның полиграфия бүлегенә турыдан-туры караган 9 Казан басмаханәсе калдырыла. 1921 ел ахырында — 1922 ел башында алар «Казпечать» трестына берләштерелә. 1922 нең 25 апрель мәгълүматларына караганда, трестта 387 квалификацияле эшче, 12 өйрәнчек, 17 кара эшче, 46 хезмәткәр эшли. Трест илнең иң куәтле полиграфия сәнәгате берләшмәләренең берсе булып тора. Аның карамагында 40 — тиз басучы, 13 «американка» тибындагы басмаханә машинасы, «бостонка» тибындагы 9 машина, 3222 пот — рус, 770 пот татар шрифты була. 1922 ел дәвамында Бөгелмә, Алабуга, Чаллы, Спас, Чистай шәһәрләре басмаханәләре «Казпечать» тресты составына кертелә, шуның нәтиҗәсендә Татарстан «Т.» полиграфия сәнәгате берләшмәсе барлыкка килә. 1923 нең апрелендә «Т.» һәм Татарстан дәүләт нәшрияты берләштерелә, алар җирлегендә Татарстан нәшрият һәм матбугат комб-ты оеша (к. *Татарстан китап нәшрияты*). Кульязмаларны әзерләү, аларның полиграфик эшләнеше һәм әзер продукцияне сату бер пр-тиедә гамәлгә ашырыла.

*Әд.:* Гафуров В.З., Мифтахова З.З. Развитие полиграфии и печати в Татарстане. К., 1977.

**ТАТПИЩЕПРОМСОЮ́З**, к. *Татарстан азык-төлек җитештерү кәсепчелеге берлеге.*

**«ТАТПОЛИГРА́Ф»**, к. *Полиграфия комбинаты.*

**«ТАТПОТРЕБСОЮ́З»** к. *Сатып алучы-кулланучылар кооперациясе.*

**ТАТПРОМСОВЕ́Т**, к. *Татарстан кәсепчелек кооперативлары советы.*

**ТАТРАЗНОПРОМСОЮ́З**, к. *Татарстан күп төрле кәсепчелекләр берлеге.*

**ТАТСЕЛЬКРЕДСОЮ́З**, к. *Татарстан авыл хуҗалыгы һәм кредит кооперациясе берлеге.*

**«ТАТСЕЛЬХОЗТЕ́ХНИКА»**, а.х. пр-тиеләрен инженер-техник тәэмин итү, җитештерү-техник хезмәт күрсәтү һәм а.х. техникасын ремонтлау буенча махсуслаштырылган берләшмә. 1961 елда респ-каның ремонт-техника станциясе җирлегендә булдырыла. «Т.» эшләгән елларда якынча 40 гомуми билгеләнештәге ремонт остаханәләре төзелә һәм реконструкцияләнә. «Т.»ның барлык район бүлекләрендә терлекчелек фермаларына, тракторлар, автомобильләргә техник хезмәт күрсәтү станцияләре, кыш көне эшли торган автотранспорт өчен гаражлар, урып-җыю техникасын һәм башка корылмаларны ремонтлау депосы булдырыла; Казан, Чистай, Бөгелмә автомобильләр ремонтлау з-длары, Чаллыда тракторлар ремонтлау буенча ремонт-механика з-ды төзелә; двигательләр (Арча), үзйөрешле машина агрегатларын (Хуҗамәт), Т-150К тракторларын һәм аларның агрегатларын (Теләче) ремонтлау буенча махсус бүлекләр реконструкцияләнә. Станок җиһазларын ремонтлау өчен «Т.»ның махсус «Борисоглебский» бүлеге булдырыла. Өч баскычлы ремонт-хезмәт күрсәтү базалары оештырыла (хуҗалык, район, респ-ка махсус пр-тиеләре һәм тәэмин итү базалары). 1981–85 тә «Т.» — Дәүләт ком-ты. Ул бетерелгәннән соң, пр-тиеләр район агросәнәгать берләшмәләре карамагында була. 1991 дә Респ-ка «Т.» ҖБ оештырыла, 1994 тә ул «Т.» холдинг компаниясе» АҖ итеп үзгәртелә. Аның район пр-тиеләре дә акционерлаша. «Т.» составына (1994–2005 тә) төрле милек формасындагы 72 пр-тие керә: анда эшләүчеләр саны 10 мең кешедән арта. Алар якынча 80 мең берәмлек үзйөрешле техникасы һәм 170 мең берәмлек тагылма һәм асылма җиһазлары булган а.х. товарлары җитештерүче 1,5 мең хуҗалыкка хезмәт күрсәтә.

1990 елларда «Т.» остаханәләрендә ел саен 3 мең трактор, 1 меңнән артык бөртекле ашлык һәм 500 терлек азыгы комбайннары, 6,5 мең дизель двигателе, а.х. машиналарының 32 меңнән артык төрле агрегатлары яңартыла. «Т.» бүлекчәләрендә (Берёзовка, Минзәлә, Саба, Түбән Кама) турбокомпрессорлар, гидротрансмиссия, терсәкле вал, күчергечләр тартмасын ремонтлау буенча махсус участоклар эшли. Детальләрне яңарту хисабына а.х. пр-тиеләренең запас частьларга ихтыяҗлары 30–35% ка канәгатьләндерелә, ремонт чыгымнары ике тапкыр кими.

«Т.» бүлекчәләрендә 15 исемдәге а.х. машиналарын серияләп җитештерү җайга салына: шикәр чөгендере чәчү өчен «Мульткорм» чәчкечләре, Л-6 чөгендер төягечләре (Бөгелмә), ПР-400 пресс-җыйгычы (Кукмара), КИР-1,5 чапкыч-ваклагычы (Питрәч) һәм якынча 2 мең исемдә запас частьлар, шуларның 120 исемдәгесе серияләп чыгарыла.

Порошок металлургиясе, корыч һәм чуен коелмалар әзерләгәндә лазер б-н металл кисү һәм материалларны ныгыту участоклары, резина һәм полимер материаллардан детальләр, дельта-агачтан подшипниклар, электродлар, автомобиль рессорлары, коелю һәм тимерчелек-пресслау җиһазлары өчен эшләнмәләр, культиваторлар, орлык чәчкечләр ясау участоклары эшли.

«Т.»ның 44 техник хезмәт күрсәтү станциясе бар, алар терлекчелектә 10 меңнән артык күчмә һәм стационар сөт саву аппаратының һәм 1050 суыткыч җайланманың, 12,3 мең тирес җыю транспортёрының, 1126 терлек азыгы цехының, 2137 терлек азыгы тарату җайланмасының, 650 витаминлы он агрегатының һәм 800 дән артык бөртекле ашлык чистарту-киптерү комплексының, 500 сөтүткәргечнең төзек эшен тәэмин итәләр. 1996–2000 дә «Т.»да авылларда торак пунктларга газ кертү буенча уннарча бригада эшли. «Т.» район АҖләренең махсус отрядлары тарафыннан 1990 ның ахырында — 2000 еллар башында терлек азыгының яртысы әзерләнә, бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культураларның якынча 10% ы суктырыла.

«Т.» автотранспорты б-н ел саен 3 млн. *т* дан артык йөк ташыла. Тәэминат базаларының товар әйләнеше елына 300–450 млн. сум тәшкил итә. «Т.»да уку үзәге, «Полигон» сынау үзәге һәм «Центрлаб» лаб-ясе бар.

А.х. пр-тиеләренең базар мөнәсәбәтләренә күчүе, түләүгә сәләтсезлеге, югары конкуренция һәм җитештерү процессына чит ил техникасын күбрәк кертү «Т.» холдинг компаниясе»н банкротлыкка китерә һәм 2005 тә аның эшчәнлеге туктала.

«Т.» җитәкчеләре: С.В.Рязяпкин (1961–64), Н.Г.*Энвальд* (1964–90), Ә.М.Залаков (1991–95), М.Г.Фәттахов (1995–2001), А.А.Шәрәпов (2001–05).

*Әд.:* Открытое Акционерное общество «Холдинговая компания» Татсельхозтехника». К., 2001.

*И.Н.Афанасьев.*

**«ТАТСОЦБА́НК»**, ТРның универсаль коммерция акц. банкы. «Жилсоцбанк» Татарстан Респ-касы идарәсе җирлегендә 1990 елда оештырыла. «Жилсоцбанк» идарәсе үз чиратында Татарстан Респ-касы конторалары: СССР Дәүләт банкы һәм СССР Төзелеш банкы җирлегендә оеша (1998). Т.ның төп оештыручысы һәм акционеры — ТР Президентының резерв фонды. Банкның башка акционерлары: «*Серго исемендәге завод*», Югары Ослан р-ның «Ослан» ит комб-ты һ.б. юридик һәм физик затлар. ТР икътисадының сәнәгать, төзелеш, сәүдә, торак-коммуналь хуҗалык кебек төрле тармак пр-тие һәм оешмаларына банк хезмәте күрсәтү «Жилсоцбанк»тан «Т.» вазифасына күчә. 1992 дә ТРда беренчеләрдән булып «Т.» РФ Үзәк банкыннан валюта хезмәте күрсәтүгә ген. лицензия ала, бу исә аның эшчәнлек даирәсен шактый киңәйтә. «Т.» — Мәскәү валюта биржасы әгъзасы, клиентларына халыкара исәп-хисап практикасында кабул ителгән барлык формаларны файдаланып хезмәт күрсәтү хокукына ия. «Т.» чит ил банклары (мәс., Германиянең Коммерция банкы һ.б.) б-н турыдан-туры корреспондентлык мөнәсәбәтләре урнаштыра; РФ банклары б-н турыдан-туры корреспондентлык мөнәсәбәтләрендә, вакытлыча хәрәкәтсез яткан акча средстволарын урнаштыру буенча халыкара базарда актив эшли.

ТРның әйдәп баручы банкларыннан берсе буларак, «Т.» күп кенә банкларның («Татагропромбанк», «Татфондбанк», «Ипотека-Инвест», «Зенит», «Спурт» һ.б.) кредиторы булып тора. ТРның өстенлекле тармакларына һәм пр-тиеләренә кредит бирә. Банкның клиентлары — Татарстанның эре җитештерү пр-тиеләре.

«Т.» эре, урта һәм кече эшмәкәрлекне үстерү буенча ТРның комплекслы программасын тормышка ашыруда катнаша, бурычлар буенча РФ дәүләт гарантияләре билгеләнгән банклар төркеменә керә. «Т.» кертемнәрне мәҗбүри иминиятләштерү системасында катнашучы банклар реестрына теркәлгән (2005). 2015 тә банкның устав капиталы 4,0 млрд. сум, үз акчаларының гомуми күләме 5,3 млрд. сум тәшкил итә.

**«ТАТСОЮ́З ХӘБӘРЧЕСЕ́»**, журнал; к. «*Вестник Татсоюза*».

**«ТАТСТРО́Й»**, ТРда сәнәгать продукцияләрен җитештерүче, җитештерү, торак, соц.-мәдәни һәм көнкүреш билгеләнешендәге объектлар төзүне тормышка ашыручы иң эре оешмаларның берсе. Тарихы Казандагы 1 нче дәүләт универсаль төзелеш конторасына нигез салынган вакыттан башлана (1921). Исеме берничә тапкыр үзгәрә: 1922 елдан — «Госуниверстрой» конторасы, 1923 тән — Бөтенроссия «Госстрой» дәүләт төзелеш конторасының Казан өлкә бүлеге, 1925 тән — «Т. конторасы, 1930 дан — Татар дәүләт төзелеш индустриясе һәм төзелеш материаллары сәнәгате берләшмәсе («Татарстройобъединение»), 1933 тән — «Т.» тресты, 1937 дән — 32 нче трест, 1939 дан — «Казаньпромстрой» тресты, 1940 тан — 12 нче төзелеш-монтаж тресты, 1941 дән — 12 нче аерым төзелеш-монтаж часте, 1946 дан — «Казаньпромстрой» тресты, 1949 дан — 40 нчы төзелеш тресты, 1961 дән — 2 нче төзелеш-монтажлау тресты, 1966 дан — «Татарстан җитештерү төзелеш-монтаж берләшмәсе», 1970 тән — ТАССРда төзелеш буенча баш идарә («Главтатстрой»), 1988 дән — «Т.» терр. төзелеш берләшмәсе, 1991 дән — «Т.» дәүләт төзелеш-сәнәгать концерны. 1994 тә «Т.» АҖ төзелә. Пр-тие эшчәнлегенең төп юнәлеше оештырылган вакыттан сәнәгать объектларын һәм иҗтимагый биналар корудан гыйбарәт була. 1920 еллар ахырында — 1930 еллар башында кирпеч һәм тимер-бетон з-дларын, агач эшкәртү комб-тын, сан.-техника һәм электромонтаж эшләре конторасын, су, җигүле, автомобиль һәм тимер юл транспортын, карьерларны, урман эшкәртүләрне эченә алган зур оешмага әверелә. Трест *Казан–Яшел Үзән сәнәгать төйнәлешен*, ш.у. Кукмара посёлогын, Волжск шәһәрен һ.б.ны индустрияләштерүгә хәлиткеч өлеш кертә; Бөек Ватан сугышы елларында эвакуацияләнгән һәм яңа оборона пр-тиеләре өчен барлык төзү-монтажлау эшләрен башкара.

«Т.»ның Казанда төзелгән аеруча мөһим объектлары арасында — Татар опера һәм балет театры (1957), Үзәк стадион (1960), Казан циркы (1967; СССР МС бүләге, 1972), «Татарстан» кунакханәсе (1970), Актёрлар йорты (1971), Газета-журналлар нәшрияты комплексы (1973), Көнкүреш йорты (1974), Үзәк универсаль кибет (1977), Казан ун-тының биек биналары һәм мәдәният-спорт комплексы (1977–91), «Сәламәтлек» комб-ты (1977), Татарстан Рәссамнар берлегенең Күргәзмәләр залы (1979; ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1981), Химиклар (1969), Төзүчеләр (1975) мәдәният сарайлары, Аяк киемнәре йорты (1983), Татар акад. театры (1986). Шулай ук Казан авиация һәм моторлар төзү берләшмәләре, «Казаноргсинтез», «Тасма», «Казанрезинотехника», «Радиоприбор», Казан оптика-механика з-ды һ.б. сәнәгать пр-тиеләре җитештерү куәтләре; Казан авиация, төзүче инженерлар, вет., а.х., мед. һәм химия-технол. ин-тларының уку биналары; Казанда шактый зур күләмдә торак, күпсанлы мәктәпләр, балалар бакчалары, поликлиникалар, клублар, кинотеатрлар, Яшел Үзән шәһәрендә күп кенә объектлар һәм биналар, респ-каның байтак р-ннарында бик күп авыл объектлары төзелә.

1990 еллар башында «Т.» генподрядлы төзелеш-монтажлау оешмаларыннан Казан йортлар төзү комб-тын, «Казаньхимстрой», «Казаньпромстрой», 2, 3, 5 нче трестларны, җыелма тимер-бетон, бетон эшләнмәләр һәм эремәләр, агач эшләнмәләр, керамзит, руда булмаган материаллар җитештерү буенча төзелеш индустриясенең 13 пр-тиесен; махсуслаштырылган «Казанспецстрой», «Строймеханизация № 3» трестларын, «Казаньстройтранс» берләшмәсен; мәгълүмат-хисаплау тармак үзәген, конструкторлык-технологияләр проектлары ин-тын, төзелеш лаб-ясен берләштерә; эшләүчеләрнең гомуми саны 21,5 мең кешегә җитә.

1990 еллардагы икътисади кризис шартларында сәнәгать объектларында эш күләме күп тапкырлар кими, торак йортлар һәм социаль-мәдәният һәм көнкүреш файдалануындагы объектларны күпләп төзү б-н бәйле булган заказларны үтәүгә юнәлгән үзгәрешләр барлыкка килә. 1991–2009 да «Т.» көче б-н 3760107 *м*² торак (ш.и. *Тузган торакны бетерү программасы* буенча 20 мең квартира), 21,7 мең урынлы 27 мәктәп, 3040 урынлы 10 балалар бакчасы, 1025 ятак-урынлы 11 хастаханә, 1560 күренүгә исәпләнгән 11 поликлиника, ш.у. «Татнефть Арена» боз спорт сарае сафка бастырыла; ТР Зур концерт залына, Опера һәм балет театрына, Казан ратушасына (элекке Дворяннар җыены бинасы) һ.б.га реконструкция үткәрелә. Оешма Универсиада–13 объектларын әзерләү эшләрендә катнаша. «Т.»ның төп заказчылары арасында — ТР хөкүмәте, Казан, Яшел Үзән, респ-ка р-ннары хакимиятләре. «Т.» — ТРда төгәлләнгән технол. цикллы бердәм җитештерү-хуҗалык комплексы, эшләүчеләр саны — 1,4 меңнән артык кеше (2013). 18 бүлендек пр-тиене (ҖЧҖ) үз эченә ала, алар арасында — төзелеш-монтажлау, тимер-бетон эшләнмәләр һ.б. төзелеш материаллары җитештерү, автотранспорт җәмгыятьләре, «Сыйфат» лаб.-тәҗрибә аттестацияләү үзәге, уку-укыту комб-ты. Төзелеш һәм автотранспорт техникасы паркында 600 дән артык машина һәм механизмнар бар.

«Т.»да актив рәвештә төзелеш-монтажлау һәм эшкәртү эшләрендә башкарылучы яңа технологияләр үзләштерелә. Төзелеш индустриясенең гамәлдәге базаларына реконструкция үткәрелә, югары сыйфатлы яңа материаллар, конструкцияләр һәм эшләнмәләр җитештерү үзләштерелә. Чит илләрдә җыелган заманча, югары дәрәҗәдә җитештерүчән, аз энергия кулланучы җиһазлар, уңайлы технол. системалар һәм автоматик линияләр урнаштырыла, күтәрү транспорты җиһазлары, күчмә составлар һәм автомобиль паркы этаплап яңартыла һәм алмаштырыла. Проектлары фасадларының һәм эчке планлаштырылуының архитекторлар һәм заказчылар таләбе буенча үзгәрүчән, төрле конструктив чишелешле (эре панельле, каркас-панельле, монолит һ.б.), ш.у. төрле биеклектәге (аз катлыдан 17 катлыга кадәр) йортлар төзелә башлый.

1971 дә «Казаньхимстрой» тресты «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә. Базар мөнәсәбәтләренә күчү шартларында нәтиҗәле эшләгәне өчен, «Т.»га «Бирменгем факелы» халыкара бүләге бирелә (1995). «Т.» хезмәткәрләренең күпчелеге дәүләт бүләкләренә, ш.и. 1 кеше Соц. Хезмәт Герое исеменә лаек була. Җитәкчеләре арасында — А.П.Секлюцкий (1921–22), К.И.Лапин (1927–36), В.В.Даниличев (1948–53), Г.К.Чудесников (1956–61), П.Д.*Тунаков* (1966–70), В.Г.Абышев (1970–74), А.Н.Маршев (1974–78), Н.Г.*Калашников* (1979–99), Н.Г.Якупов (2000–06), Р.В.Адаев (2006–09), Л.З.Гобәйдуллин (2009 дан).

*Әд.:* Архитектурно-строительный комплекс Республики Татарстан: История, биографии, свершения, надежды. К., 2005.

*С.Г.Белов.*

**ТАТСТРОЙМЕТАЛЛПРОМСОЮ́З**, *Татарстан төзелеш материаллары һәм металл эшкәртү кәсепчелеге кооперативлары берлеге.*

**«ТАТТРАНСГА́З»** («Газпром трансгаз Казан»), «Газпром» АҖнең кече газ-транспорт пр-тиесе, ТР җылылык-энергетика комплексының иң зур пр-тиеләреннән берсе. Үз хезмәт күрсәтү зонасында (ТР терр-ясе һәм күрше төбәкләр терр-яләренең бер өлеше) РФнең Бердәм газ тәэминаты системасының магистраль газүткәргечләрен эксплуатацияли, түбән басымлы газ бирү челтәрләренә хезмәт күрсәтә, газ тәэминаты системаларын проектлый, гамәлдәге газүткәргечләрне һәм газ хуҗалыгы объектларын ремонтлый, РФ һәм ТР кулланучыларына углеводород чималын китерүне гамәлгә ашыра. 1955 елда Казан магистраль газүткәргечләр идарәсе буларак оештырыла, берничә тапкыр исемен үзгәртә: 1969 дан Магистраль газүткәргечләрнең Казан районы идарәсе, 1971 дән Казан линияле-җитештерү диспетчерлык хезмәте, 1974 тән газ күчерү һәм китерү буенча «Т.» ЖБ, 1981 дән табигый һәм сыегайтылган газ китерү һәм сату буенча «Средневолжскгаз» ЖБ, 1988 дән «Т.» магистраль газүткәргечләр идарәсе, 1991 дән «Газпром» дәүләт газ концерның «Т.» пр-тиесе, 1993 тән «Т.» ҖЧҖ, 2008 дән «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ.

Пр-тие баштарак Миңлебай–Казан һәм Миңлебай–Урыссу–Түбәнкүл магистраль

газүткәргечләренә (гомуми озынлыгы 376 *км*, алар буенча Миңлебай газ-бензин з-дыннан ягулык газ күчерелә) һәм өч газ бүлү станциясенә (ГРС) хезмәт күрсәтә. Пр-тие структурасына 3 авария-ремонт пункты керә. 1954–55 тә бу газүткәргечләр буенча газ В.И.Ленин исем. Казан химия з-дына, Урыссу ГРЭСына, Казан, Бөгелмә һәм Урыссу штпның торак йортларына китерелә башлый. Шуннан соң газлаштырылган торак пунктлар саны арта бара. 1957 дә, Казан–Горький газүткәргече сафка кертелгәннән соң, газүткәргечләрнең гомуми озынлыгы 854 *км* га җитә, газ Әлмәт, Лениногорск, Чистай шәһәрләренә җибәрелә башлый. 1965 тә Миңлебай–Йошкар-Ола газүткәргече файдалануга кертелә, газ ягулыгы Зәй һәм Яшел Үзән халкына да барып җитә. 1955–65 тә газ китерү күләме 37 тапкыр арта һәм елына 1 млрд $м^3$ га җитә; газүткәргечләрнең гомуми озынлыгы 1273 *км* тәшкил итә, 12 ГРС эшли.

1966–72 дә, СССРда беренче булып, 292 *км* озынлыктагы Миңлебай–Казан продуктүткәргече буйлап, ерак арага сыегайтылган газ китерү гамәлгә ашырыла һәм шуның нәтиҗәсендә Казан органик синтез з-ды углеводород чималы б-н тәэмин ителә. Берничә ГРС һәм Түбән Кама, Чаллы, Алабуга, Менделеев шәһәрләренә газүткәргеч тармаклары файдалануга тапшырыла, Түбән Кама нефть химиясе комб-тына чимал китерелә башлый. 1970 еллар башында беренче тапкыр респ-ка авыл районнарында газүткәргеч тармаклар һәм ГРСлар төзүгә һәм аларны табигый газ б-н тәэмин итүгә керешелә (1950 еллардан торак фондлар сыегайтылган баллонлы газ б-н газлаштырыла).

1972–73 тә газны Түбән Тура–Пермь–Казан–Горький–Үзәк магистраль газүткәргеченнән ала торган газүткәргеч төзелә. Газ Арча, Саба, Кукмара, Питрәч, Минзәлә р-ннары үзәкләренә бирелә башлый. 1970 еллар ахырына респ-када ел саен 35–65 *км* газүткәргеч төзелә һәм 1000 гә якын фатирга газ кертелә. Оренбург–Казан этанүткәргечен төзеп бетергәннән соң (Әлмәт р-нының Аппак авылындагы пункты б-н бергә), илдә беренче тапкыр магистраль торбаүткәргеч буйлап үтә критик режимда этан фракциясен күчерү процессы үзләштерелә. 1983–86 да Түбән Кама терр.-җитештерү комплексына газүткәргеч тармагы сафка кертелә. Газ җирле электр-җылылык үзәкләрендә ягулык буларак кулланыла башлый, Актаныш, Балтач, Биләр, Буа, Базарлы Матак, Нурлат, Сарман, Мамадыш, Мөслим, Чирмешән район үзәкләре һәм торак пунктлары газлаштырыла. 1985 тә «Т.»ның тәкъдиме һәм турыдан-туры катнашы б-н, РСФСР төбәкләре арасында беренче булып, Татарстан АССРын газ б-н тәэмин итүнең ген. схемасы һәм адм. районнарын газлаштыру схемалары эшләнә. 1990 да авылларны газлаштыру дәрәҗәсе 5% булса, 1995 тә 35,5% ка җитә. Бу күрсәткечләр б-н респ-ка Россиянең беренче 10 алдынгы төбәге арасына керә.

1963 тән газлаштырылган объектлардан файдалану һәм кулланучыларга хезмәт күрсәтү эшен — ТАССР МС каршындагы Газ хуҗалыгы идарәсе, 1977 дән — «Татгаз» ЖБ, 1990 нан газүткәргечләр һәм газ хуҗалыгын проектлаштыру, төзү һәм эксплуатацияләү буенча «Татстройгазификация» пр-тиесе алып бара, соңгысы 1996 да «Т.» составына кертелә.

1995 тә «Газпром» АҖ һәм ТР МК арасында берничә махсус килешү төзелә, ТР районнарын, шәһәрләрен һәм авылларын газлаштыру программасы кабул ителә. Шулар нигезендә 1995–2001 дә респ-када 340,4 *км* газүткәргеч тармак, 30 автомат ГРС, түбән басымлы 18608,4 *км* газүткәргеч төзелә һәм файдалануга тапшырыла, 329629 фатирга газ кертелә. 2003 тә Уренгой–Ужгород һәм Казан–Түбән Новгород магистраль газүткәргечләр арасында тоташтыргыч газүткәргеч төзелү б-н, Татарстанның Идел алды р-ннары һәм Чуаш Респ-касы, Ульянов өлкәсенең дүрт р-ны ышанычлы газ тәэминатына ирешә. Табигый газ ТРның барлык адм. районнарына кадәр үткәрелеп бетә. Респ-ка газлаштыру дәрәҗәсе 98,7% ка, ш.и. шәһәр һәм шәһәр тибындагы посёлокларда — 99,6% ка, авылларда 97,2% ка җитә. Бу күрсәткечләр буенча Татарстан Россиядә иң алдынгы урынны тота.

2010 елга пр-тие 5,7 мең *км* дан артык магистраль газүткәргечләрне, 39 мең *км* дан артык газ бүлү үткәргечләрен, 7 меңнән артык газ көйләү пунктын, «Арча» компрессор станциясен («Газпром» АҖдә иң зурларның берсе) файдалана. Соңгысы экспорт үткәргечләрен дә кертеп, 7 газүткәргеч линиясенә хезмәт күрсәтә (Уренгой–Ужгород, Уренгой–Үзәк-1, Уренгой–Үзәк-2, Ямбург–Елец-1, Ямбург–Елец-2, Ямбург–Көнбатыш чик буе һәм Түбән Тура–Пермь–Горький). Магистраль газүткәргечләр буйлап РФнең үзәк төбәкләренә, якын һәм ерак чит илләргә ел саен 260 млрд. $м^3$ дан артык, ш.и. ТРда 15,0 млрд. $м^3$ дан күбрәк табигый газ китерелә. «Т.» 14670 тән артык сәнәгать, коммуналь-көнкүреш, а.х. пр-тиесе һәм җылыту котельныйларының газ җиһазларына, респ-ка халкының фатирларындагы һәм өйләрендәге 1923900 берәмлек газ җиһазына техник хезмәт күрсәтә. Пр-тие структурасына магистраль газүткәргечләрнең 3 җитештерү-линия идарәсе, Казандагы баш идарә керә; эшләүчеләр саны — 10 меңнән артык кеше (2014).

Газ куллану өлкәсен киңәйтү буенча актив эш алып барыла (мәс., автомобиль ягулыгы сыйфатында). Респ-када автомобильләргә табигый газ ягулыгы тутыру өчен газ баллоннары кую һәм аларны тикшерүдә тоту буенча 3 участок, Казанда, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Мамадыш, Бөгелмәдә 8 газ тутыру станциясе, «Арча» компрессор станциясе эшли. Пр-тиенең тырышлыгы б-н табигый һәм сыегайтылган нефть газын мотор ягулыгы сыйфатында куллану буенча респ-ка комиссиясе төзелә, ТР МК тарафыннан 2004–2010 елларда ТР автомобиль транспортында газ-мотор ягулыгын арттыру концепциясе, «2013–2023 елларда Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» дәүләт программасы кабул ителә.

Пр-тиедә социаль инфраструктураны камилләштерүгә, хезмәткәрләрнең торак шартларын яхшыртуга, аларны сыйфатлы медицина хезмәте б-н тәэмин итүгә, ялларын оештыруга зур игътибар бирелә. Корпоратив һөнәри белем бирү актив кертелә, пенсия исәпләүнең тармак системасы үстерелә һ.б. Күп кенә хезмәткәрләр дәүләт бүләкләренә лаек була.

Пр-тие җитәкчеләре: Г.В.Шерпутовский (1955–61), И.Ю.Сәйдәшев (1961–73), Д.Т.Әхмәтов (1973–75), Г.Х.*Газизов* (1975–93), Р.Г.*Мөслимов* (1993–98), Р.Г.*Кантюков* (1998 дән).

*Әд.:* К у з н е ц о в Л. «Вся республика согрета голубым огнём твоим...» (к 50-летию Таттрансгаза) // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2005. № 2; Таттрансгазу — 50 лет // Газовая промышленность. 2005. № 6.

*М.В.Андрианов.*

**ТАТУТИЛЬПРОМСОЮ́З**, к. *Татарстан чимал калдыкларын җыю һәм эшкәртү кәсепчелеге кооперацияләре берлеге.*

**«ТАТФЛО́Т»**, к. *Елга транспорты.*

**«ТАТФОНДБА́НК»**, инвестицияләү универсаль коммерция акц. банкы (АИКБ «Татфондбанк» АҖ). Корпоратив клиентларга һәм хосусый затларга күптөрле хезмәт күрсәтүче универсаль банк. 1994 елда оештырыла. Татарстанның һәм Идел буе төбәгенең эре банкларыннан берсе, РФ төбәк банклары арасында беренче унлыкка керә, активлары һәм үз капиталының күләме буенча РФнең 50 эре банкы арасында.

Банкның устав капиталының 5% тан артыграгына ия эре акционерлар: «Татагролизинг» җәмгыяте (24,2%), «Ак Барс» банкы (номиналь акционер, 21,3%), «Депозитар-Клиринг Компаниясе» (номиналь акционер, 7,5 %), «Селена-Нефтехим» (8,3 %), «Артуг-Финанс» (6,4 %) ҖЧҖ. «Т.» һәм аның ф-лларында 15 меңләп корпоратив клиентка хезмәт күрсәтелә, алар — респ-каның әйдәп баручы пр-тие һәм оешмалары, кече һәм урта бизнес вәкилләре, хосусый эшмәкәрләр. Банк, нигездә, ТР икътисадының реаль секторын финанслый.

«Т.» халыкка күптөрле хезмәт күрсәтә. «Т.» «MasterCard Worldwide», «Visa International» халыкара түләү системаларының пластик карталарын чыгара һәм аларга хезмәт күрсәтә. Регионнар б-н эшләүче ТР банклары арасында «Т.» алдынгы позициядә.

Банк фонд базарында эшли. 2015 тә Moody's агентлыгының B3 дәрәҗәсендәге (фараз — «тотрыклы») кредит рейтингына ия булуы Россия банклары ягыннан да, чит илләрнең финанс ин-тлары тарафыннан да «Т.»ка ышанычның ныгуын раслый; 2006 да Moody's «Т.»ның озак сроклы рейтингын чит ил валютасындагы депозитлар буенча «тотрыклы»дан (B3) «позитив»ка (B2) үзгәртә. Банкның финанс тотрыклылыгы (E+) рейтинглары һәм депозитлар буенча (NP) кыска сроклы рейтингы «тотрыклы» буларак расланды. 2009 ның 1 февраленә чит ил валютасындагы депозитлар буенча озак сроклы рейтингы — «позитив» (B3); чит ил валюта-

сындагы депозитлар буенча кыска сроклы рейтингы — NP, финанс тотрыклылыгы рейтингы — Е+, милли шкала буенча озак сроклы кредит рейтингы — Baal.

«Т.»та корреспондент банкларның ныклы челтәре формалашкан, 30 банк, ш.и. Германия, Франция, Швеция банклары б-н корреспондентлык мөнәсәбәтләре җайга салынган: РФ «Т.»ының төп корреспондентлары — «Альфабанк», «Газпромбанк», «Внешэкономбанк», «Ак Барс» һ.б. эре банклар.

«Т.» ТРда, Чабаксар һәм Пермь шәһәрләрендә хәйриячелек һәм спонсорлык эшчәнлеге социаль-икътисади программаларын тормышка ашыруда актив катнаша. Мәсәлән, 2007 дә хәйриячелек максатларына (сугыш ветераннары һәм инвалидларына, балалар һәм мәдәният учреждениеләренә, югары уку йортларының фәнни эшчәнлегенә ярдәм итүгә һ.б.) 45 млн. сумга якын акча бирә.

«Т.» активы һәм үз капиталы суммасы буенча Россиянең иң эре банклары исәбендә. 2015 нең 1 сентябренә аның актив 190,3 млрд. сум, үз капиталы 22,2 млрд. сум тәшкил итә.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**«ТАТХИМФАРМПРЕПАРАТЛА́Р»**, медицина сәнәгате пр-тиесе. Казанда урнашкан. Эшләүчеләр саны — 1 мең чамасы кеше (2014). Тарихы 1855 елда фармация магистры Ф.Х.Грахе нигезләгән фирмадан башланып китә, 20 йөз башына бирелә дару препаратлары — үсемлекләр нигезендә галеннар һәм терлек чималыннан альбуминатлар (ш.и. 1878 дә — илдә беренче каты желатин капсулаларга тутырылган дарулар), ш.у. җәрәхәт бәйләү һәм косметика чаралары, ясалма минераль сулар, башка эчемлекләр һ.б. җитештерү җайга салынган була. Продукция ваклап та, хастаханә һәм даруханәләргә күпләп тә сатыла. Беренче бөтендөнья сугышы елларында, башлыча, сугыш заказларын үти.

Национализацияләнгәннән соң (1918), фирманың бүлекчәләре Татарстан мед. сәүдәсе, Татарстан аптекалар идарәсе карамагында була. 1931 дә алар җирлегендә — Октябрьнең 14 еллыгы исем. химия-фарм. ф-касы, 1939 да 11 нче химия-фарм. з-ды (290 нан күбрәк кеше эшли) оештырыла. 1930 елларда җиһазлар өлешчә яңартыла, җитештерү мәйданнары киңәйтелә, крахмал (капсула) чыгару оештырыла, дару үләннәре үстерү тәҗрибә участогы киңәйтелә. Бөек Ватан сугышы елларында пр-тие Казанга эвакуацияләнгән М.Ломоносов исем. Киев химия-фарм. з-ды (илдә иң зур), Ленинград һәм Мәскәүнең шундый ук з-длары куәте исәбенә шактый үсеш ала һәм фронтны медикаментлар б-н тәэмин итүдә әйдәп баручы пр-тиегә әверелә. Күптөрле дарулар — ялкынсынуга каршы, йөрәк һәм инъекцияләр өчен, көчле авыруларны дәвалау, кан консервлау, наркоз, стоматология өчен препаратлар, ш.у. рентген җайланмалары өчен экраннар һәм рентген карталары өчен барий сульфаты җитештерелә башлый; җәрәхәтне тиз төзәтә торган майлар, гөлҗимеш таблеткалары, йогышсызландыру препаратлары чыгару тагын да арттырыла; заводта эшләнгән бинт чорнау ста-



«Татхимфармпрепаратлар».
Таблеткалар тутыру участогы.

ногы әлеге продукцияне ике тапкыр артыграк чыгару мөмкинлеге бирә.

1948 дә з-д дозаланган һәм кулланууга әзер дару препаратлары әзерләп чыгаруга күчә һәм гамәлгә конвейерлар кертү башлана. 1950 елларда Буров сыекчасын уникаль электролитик юл б-н җитештерү, илнең барлык биологик ф-каларына җибәрелә торган гидроксал эшләп чыгару оештырыла. Завод ш.у. кальцекс, уротропин, уросал, уробесал һ.б. кыйммәтле дару препаратларын ил күләмендә бердәнбер җитештерүче була. 1950 еллар ахырына биредә, Казан химиклары һәм фармакологлары б-н хезмәттәшлек нигезендә, дөньяда беренче тапкыр күп кенә *фосфорорганик дару кушылмаларын* синтезлау үзләштерелә. 1966–68 дә пр-тиене яңа сәнәгать мәйданына күчерү нәтиҗәсендә җитештерү мәйданнары 5 тапкыр арта, һәм з-д елга 223 млн. тартмага кадәр әзер дару эшләп чыгару куәтенә ирешә. 1975 тә Казан химия-фарм. з-ды җирлегендә Казан «Алга» (1976 дан «Т.») химия-фарм. ҖБ төзелә, аңа ш.у. Казан кетгут з-ды да (1929–30 да төзелә һәм илдә терлек чималыннан күпләп кетгут җитештерүче бердәнбер з-д була: елына 35 млн. погон метрга кадәр продукция җитештерә; биредә беренче тапкыр мед. эшләнмәләрен нурланыш (радиация) юлы б-н йогышсызландыру алымы кулланыла) керә. 1975–78 дә яңа, хирургик тегү материаллары з-ды сафка кертелә, анда Көнбатыш Европаның алдынгы фирмаларының лицензияләре булган җиһазлар һәм технологияләр файдаланыла. Кетгут б-н беррәттән хирургик ефәк җитештерү җайга салына. 1980 елларда берләшмәдә, дөньяда беренче булып, глаукоматоз авыруларын дәвалау өчен миопатик чараларны серияләп җитештерү үзләштерелә. Җитештерүгә автоматлар, ярымавтоматлар һәм агымлы конвейер линияләрен актив кертү нәтиҗәсендә, эшләп чыгарылган дару күләме елына 300 млн. тартмага җитә. Әлеге күрсәткеч буенча ҖБ илнең иң зур 5 мед. пр-тиесе исәбенә керә.



«Татхимфармпрепаратлар».
Дару продукциясе үрнәкләре.

1990 елларда яңа төр эшләнмәләр, ш.и. таспир һәм микройодид кебек үз эшләнмәләрен үзләштерү дәвам итә. 2000 дә ҖБгә халыкара ИСО 9001:2000 сыйфат стандарты сертификаты бирелә. 2005 тә гален җитештерүенә реконструкция үткәрелә. 2008 дә өр-яңа Германия, Италия, Чехия җиһазлары куелган каты дару препаратлары цехы ачыла; ул елына дару чаралары җитештерүчеләрнең Европа стандарты (GMP) таләпләренә туры килүче 1,5 млрд. төймәле һәм 250 млн. капсулалы дару эшләп чыгару сәләтенә ия. Пр-тие продукциясе ассортиментында — 100 дән артык исемдә әзер дару матдәсе бар, алар төймә, май, төнәтмә, сироп, эремә һәм паста рәвешендә чыгарыла һәм 30 фармакологик төркемгә карый: йөрәк-кан тамырлары дарулары, ялкынсынуга, вирусларга, микробларга каршы, антигельминт, глаукомага, шешенүгә каршы, антибиотик, анальгетик, нейролептик, транквилизаторлар һ.б. дару төркемнәре. «Т.» — Россиядә организмга тарала һәм таралмый торган натураль һәм синтетик полимер хирургик тегү материалларын төрле үлчәмнәрдә һәм максатларда җитештерүче иң зур пр-тиеләрнең берсе. Аның техник куәтләре елына 400 млн. га кадәр тартма дару һәм 11 млн. погон метр тегү материаллары эшләп чыгару мөмкинлегенә ия.

Продукция 1962 дән чит илләргә (Көнчыгыш Европа илләренә, Кубага, хәзерге вакытта — якын чит илләргә) чыгарыла. Халыкара «TRADE leaders» клубының «Алтын призы», Мексика Милли маркетинг ин-тының «Бриллиант йолдыз»ы (икесе дә — 1995), «Европаның алтын а́ркасы» (1996) бүләкләренә лаек була.


Берләшмә хезмәткәрләре арасында 3 кеше — Ленин ордены, 12 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 5 кеше — «Почёт билгесе», 4 кеше 3 нче дәрәҗә Хезмәт даны орденнары б-н бүләкләнә, 1 кеше — ТР Дәүләт бүләге лауреаты.

Пр-тие җитәкчеләре арасында — Ф.Х.Грахе (1855–1905), Э.Ф.Грахе (1905–18), С.Ф.Бәширов (1931–33), А.Т.Буев (1933–39), Т.А.Рассыпнинская (1940–50, 1957–65), И.Г.*Гыйльметдинов* (1965–93), Р.Х.Гомәров (1993–2004), А.К.Хамаев (2004–08), Т.Ш.Ханнанов (2009 дан).

*Әд.:* На службе здоровья и долголетия. К., 1981.

*С.Г.Белов, М.В.Сәлигәрәев.*

**ТАТЦИ́К ИСЕМЕНДӘГЕ́** авыл, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 6 *км* көньяктарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 161 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. Башлангыч мәктәп. 1930 елларда нигез салына. Халык саны: 1949 да — 172, 1958 дә — 131, 1970 тә — 164, 1979 да — 152, 1989 да — 123, 2002 дә — 162 кеше.





«Татэлектромаш».
1–2. Авыр йөк автоүзбушаткычлары өчен ЭК-420А һәм ДК-722Е электр двигательләре;
3. Шәһәр электр транспорты өчен ДН-305 электр двигателе.

**ТАТШВЕЙТЕКСТИЛЬПРОМСОЮ́З**, к. *ТАССР туку-тегү кәсепчелеге кооперациясе берлеге.*

**«ТАТЭЛЕКТРОМА́Ш»**, холдинг компаниясе. Чаллы шәһәрендә урнашкан. 1976 елда Транспорт электр җиһазлары з-ды буларак нигезләнә. 1986 да аның җирлегендә «Т.» ЖБ оештырыла, аңа ш.у. кою з-ды һәм махсус конструкторлык-технол. бюросы да кертелә. 1989 да «Т.» — ФҖБ, 1999 да — дәүләт унитар пр-тиесе, 2000 дә «Т.» АҖ итеп үзгәртелә, 2005 тән «Т.» ФҖБ» АҖ, 2008 дән хәзерге исемдә. Завод 1980–86 еллар дәвамында сафка кертелә (проект куәтләренең 40% ы төзелә); алдынгы (ш.и. автоматлаштырылган) технол. җиһазлар б-н тәэмин ителә. Беренче продукция (ДК маркалы электр двигательләре) 1981 дә чыгарыла. Соңга таба пр-тиедә «БелАЗ» авыр йөк автоүзбушаткычлары, шәһәр һәм шәһәр яны электр транспорты (трамвай, троллейбус, электр поездлары), тимер юл машиналары өчен тарту электр двигательләре, генераторлар һәм кабызуны көйләү электр аппаратлары; краннар өчен электр двигательләре; авыр йөк күтәрүчән электромагнитлар һәм аларга идарә шкафлары, ш.у. халык куллануы товарлары: кер юу машиналары, эретеп ябыштыру трансформаторлары, мебель фурнитурасы һ.б.ны җитештерү үзләштерелә. Продукциянең күпчелек өлешен егәрлеге 3,5–630 *кВт*, массасы 175–4100 *кг* булган зур электр машиналары тәшкил итә. 1987 дә эшләүчеләр саны 4,3 мең кешедән арта, җитештерү күләме иң югары күрсәткеченә — 9 мең данә электр двигателе эшләп чыгаруга ирешә. 2001 дә 1,3 мең кеше эшли һәм 1,9 мең двигатель чыгарыла.

2002 дә АҖ структурасын оптимальләштерү һәм җитештерүләргә диверсификация уздырыла. Пр-тие мәйданнарында һәм куәтләрендә «Т.» холдингына керүче күп кенә пр-тиеләр оештырыла, алар түбәндәгеләрне башкара: электротехника продукциясе чыгару, нефть табу техникасын төзәтү («Транспорт электр җиһазлары заводы» җитештерү компаниясе» АҖ), металл конструкцияләр, сэндвич-панельләрдән тиз җыела торган корылмалар әзерләү һәм монтажлау («ТЭМПО» Кама металл конструкцияләр заводы АҖ), катлаулы пресс-формалар һәм штамплар, пластмасса һәм резинотехник эшләнмәләр, «КамАЗ» автомобильләренә запас частьлар, автокомпонентлар, тара эшләп чыгару, йөк автомобильләре һәм тагылма шассиларына төрле махсус агрегатлар һәм үзбушаткычлар җитештерү һәм урнаштыру («КамАЗ» АҖ Фәнни-техник үзәге б-н берлектә), изотермик, җылытылган һәм башка типтагы автофургоннар («Технотрон» җитештерү компаниясе» АҖ), профильле һәм түгәрәк киселешле торбалар җитештерү («ТЭМПО» Түбән Кама торба заводы» ЖЧҖ); тәҗрибә-конструкторлык һәм технол. эшләр үткәрү. Холдинг пр-тиеләрендә 2,5 мең чамасы кеше эшли (2015).

2000 еллар башында яңа производстволар сафка кертелә: төгәл кою; штамплау; а.х. техникасын (тагылма арбалар, туфрак йомшарткычлар, тырмалар) җитештерү; Белоруссия Респ-касының «Палессе» бөртекле ашлык комбайннарын җыю җайга салына. Корыч прокаты һәм арматура җитештерү буенча югары технологияле «ТЭМПО» Кама металлургия комб-тын төзү төгәлләнә.

«Т.» хезмәткәрләре арасыннан 4 кеше — ТРның атказ. машина төзүчесе, 1 кеше — РФнең атказ. конструкторы исеменә лаек була, 1 кеше — Халыклар дуслыгы, 2 кеше — «Почёт билгесе», 3 кеше 3 нче дәрәҗә Хезмәт даны орденнары б-н бүләкләнә.

Пр-тиенең җитәкчеләре: Х.Г.Сабиров (1976–78), Е.М.Бондаренко (1978–81), Н.Н.Нугис (1981–82), Я.А.Бәширов (1982–86), А.Д.Григорович (1986–97), И.С.Мәгыйзов (1997–2001), И.З.Исламов (2001 дән).

*С.Г.Белов, Г.Я.Мәүлетова.*

**«ТАТЭНЕ́РГО»**, холдинг компаниясе; ТР терр-ясендә электр энергиясе җитештерү һәм сату, җылылык энергиясен җитештерү, тапшыру һәм сату б-н шөгыльләнә. «Т.» зур индустрия һәм а.х. төбәген электр һәм җылылык энергиясе б-н тәэмин итә, респ-када урнашкан нефть чыгару һәм эшкәртү, нефть химиясе, машина төзү сәнәгатьләре пр-тиеләренең энергетика базасы булып тора.

1931 елда дәүләт электр станцияләренең район идарәсе буларак нигез салына. Бу чорда «Т.» 6 *МВт* ка кадәр егәрлекле энергия җайланмалары проектларын тикшерә һәм раслый, Казан ГРЭСын (1 нче ТЭЦ) төзү һәм файдалануга тапшыру барышына күзәтчелек итә. 1932 дә Казан энергетика комб-ты итеп үзгәртелә, 1939 да аңа *Казан җылылык-электр үзәкләре* (1 нче һәм 2 нче), 124 нче з-д һәм Мари кәгазь комб-тының (Мари АССРның Волжск ш.) җылылык-электр үзәкләре, Татреспубликаның 3 нче еллыгы исем. электр станциясе кертелә. Гомуми энергетик куәте 60 *МВт*, электр тапшыру линияләренең озынлыгы 288,4 *км* була. Казан энергетика комб-ты Казан–Зеленодольск сәнәгать төйнәлеше пр-тиеләрен энергия б-н тәэмин итә. Аның структурасында «Энергосбыт» (хуҗалык исәбе пр-тиесе хокукларында эшли, үз әченә абонентларга хезмәт күрсәтүне һәм электр счётчиклары остаханәсен ала), техника бүлекләре; һава аша һәм кабельле линияләрдән файдалану, электр челтәрләрен үзгәртеп кору хезмәтләре, диспетчерлык үзәге, релелы саклагычлар һәм автоматика хезмәте үзәге һ.б. булдырыла. 1943 тә энергокомб-т җирлегендә Казан энергетика хуҗалыгы идарәсе «Казэнерго» оештырыла. 1940 еллар ахырында — 1950 еллар башында химия хезмәте, үзәкләштерелгән яшеннән саклану һәм сынаулар хезмәте, проектлаштыру-конструкторлык бюросы төзелә. 1957 дә Татарстан ХХСның Энергетика сәнәгате идарәсе оештырыла, ул «Казэнерго» һәм «Урыссуэнерго» (1943 тә ул «Туймазыэлектроток» конторасы буларак төзелгән була) идарәләрен берләштерә. Аңа Казанның 1 нче һәм 2 нче ТЭЦлары, *Урыссу ГРЭСы* һәм *Зәй ГРЭСы*, Казан һәм Әлмәт электр челтәре идарәләре, Казандагы Җылылык челтәрләре идарәсе, «Энергосбыт» пр-тиесе кертелә; нәтиҗәдә, Казан–Зеленодольск сәнәгать төйнәлеше һәм *Әлмәт–Бөгелмә сәнәгать төйнәлешенең* энергия системалары кушыла. 1963 тә респ-каның энергетика системасы һәм электрлаштыру б-н бердәм җитәкчелек итү максатында «Т.» район энергетика идарәсе (РЭУ) оештырыла; аның карамагына ш.у. коммуналь һәм а.х.ларының электр җайланмалары һәм челтәрләре тапшырыла. Кулланучыларны район электр станцияләреннән һәм подстанцияләреннән үзәкләштерелгән электр тәэминатына күчерү башлана, аның барышында зыянга эшләүче вак электр станцияләре һәм энергия җайланмалары ябыла, электр тапшыру челтәрләре үсеш ала, булганнары үзгәртеп корыла башлый. «Т.» составында Әлмәт, Бөгелмә, Түбән Кама, Чистай, Казан һәм Идел буе (1964), Буа (1969), Алабуга (1984), Чаллы (2000) электр челтәрләре төзелә. Электр техникасы һәм җылылык механикасы җиһазларыннан файдалануга, аларны төзәтүгә, авыл хуҗалыгын электрлаштыруга караган үзәкләштерелгән җитештерү хезмәтләре, бүлекчәләр булдырыла. 1970 еллар башында энергия системасы б-н җитәкчелек итүгә хисаплау техникасы, автоматлаштырылган идарә системалары (АСУ) кертелә башлый. 1966–85 тә Казандагы 3 нче ТЭЦ, *Түбән Кама ГЭСы, Түбән Кама җылылык электр үзәге, Чаллы җылылык электр үзәге* файдалануга тапшырыла; җылылык энергетикасы көчле үсеш ала. Татарстан энер-



«Татэнерго» холдингы генераль дирекциясенең Казандагы бинасы.

гия системасының гомуми куәте 7200 *МВт* ка җитә; ул СССРдагы иң зур 7 система исәбенә керә. 1988 дә РЭУ Татарстан энергетика һәм электрлаштыру ЖБ «Т.» итеп үзгәртелә. 1991 дә пр-тие электр (36 млрд. *кВт·сәг.* тән артык) һәм җылылык (44 млн. *Гкал* дән артык) энергиясе җитештерүнең рекордлы дәрәҗәсенә ирешә.

1991 дә «Т.» ТР дәүләт органнары юрисдикциясенә күчә. 1990 елларда сәнәгать җитештерүенең түбәнәюе һәм энергиягә ихтыяҗның кимүе, кулланучыларның түли алмавы аркасында пр-тие зыянга эшли башлый. 1999 да аны финанс ягыннан терһәкләндерү программасы гамәлгә кертелә һәм 2004 тә пр-тиенең рентабельлелеге 12% ка җитә. 2001 дә «Т.», илдә беренчеләрдән булып, тәүлекнең төрле вакытында төрле тариф буенча исәпләүләр кертә. Илнең энергетика тармагын тамырдан үзгәртеп кору кысаларында «Т.» акцияләштерелә (2002), һәм анда структураларның яңача бүленеше гамәлгә ашырыла башлый. 2010 ел башына аның составына «Генерирующая компания» (электр һәм җылылык энергиясе җитештерүче 8 электр станциясен берләштерә); «Татэнергосбыт»; «Казан җылылык челтәре компаниясе», «Чаллы җылылык челтәре компаниясе», «Урыссу җылылык челтәре компаниясе» ҖЧҖ (кулланучыларга җылылык энергиясен тапшыралар һәм бу энергияне техник яктан ялгыйлар) керә. Эшчәнлекнең төп профильгә карамаган төрләре мөстәкыйль пр-тиеләргә бүлеп чыгарыла: транспорт күчерүләре, электр җиһазларын төзәтү һәм көйләү, төзелеш материаллары җитештерү, фәнни-техник, инженерлык һәм проект-конструкторлык хезмәте, персоналны укыту һ.б.

2010 ел башына холдинг электр станцияләренең гамәлдәге электр куәте 6675 *МВт*, җылылык куәте 14528 *Гкал·сәг.* була, елына 25 млрд. *кВт·сәг.* электр һәм 30 млн. *Гкал* җылылык энергиясе (ТРда җылылык кулланышының 70%ы) җитештерелә. Респ-ка ихтыяҗыннан 1000–1500 *МВт* ка артыграк өстәмә электр энергиясе бирерлек резерв куәте бар. Җылылык челтәрләренең гомуми озынлыгы 900 *км* тирәсе. Эшләүчеләр саны 23 мең кеше. 2008 дә холдинг РФдә иң күп продукция сатучы (53,4 млрд. сум) 100 эре пр-тие исәбенә керә.

«Т.» пр-тиеләрендә техник яңартып кору һәм реконструкция программасы гамәлгә ашырылып килә (2008 дә 4,5 млрд. сум инвестиция салынган), ул исә станция җиһазларының иң яңа үрнәкләрен урнаштыруны һәм югары технологияләр кертүне күздә тота; ш.и. ягулыкны уртача 25% ка кадәр кимрәк куллана һәм әйләнә-тирәгә чыга торган зарарлы матдәләрне 2 тапкырдан да күбрәк киметә торган газ турбиналы җайланмалар корыла. 2000–10 елларга исәпләнгән энергия саклау программасы үтәлә, заманча энергия саклаулы технологияләргә нигезләнгән үсеш һәм техник җиһазландыру юнәлешләренә өстенлек бирелә, ТЭЦ һәм котельныйларга пар-газ һәм газ турбиналы җайланмалар урнаштыру схемасы эшләнә. Җылылык энергиясен күчерүнең ышанычлылыгын арттыруга, кече энергетика һәм торак-коммуналь хуҗалыкларын кушуга караган эшләр алып барыла.

Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә, ш.и. 1 кеше — Соц. Хезмәт Герое, 2 кеше — Татарстанның Соц. Төзелеш Герое, 370 тән күбрәк кеше РСФСР, РФ, ТАССР, ТРның төрле халык хуҗалыгы тармакларының атказ. хезмәткәрләре исемнәренә лаек була; 14 кеше — Ленин ордены, 2 кеше — Октябрь Революциясе, 30 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 6 кеше — Халыклар дуслыгы, 48 кеше — «Почёт билгесе», 1 кеше — «Почёт», 31 кеше 3 нче дәрәҗә Хезмәт даны ордены б-н бүләкләнә.

Җитәкчеләр: В.В.Полумордвинов (1931–32), А.Г.*Ганиев* (1932–34), А.А.Терский (1934–35), А.Б.Нуруллин (1935–38), И.Ф.Никитин (1938–42), К.Х.*Мөхетдинов* (1942–52), Г.В.Комаров (1952–57), В.И.*Мишин* (1957–66), Н.В.Петров (1966–68), В.К.Шибанов (1968–78), Н.А.*Баныкин* (1978–85), В.Ф.Малов (1985–86), Р.Г.Хәйруллин (1986–97), Р.М.Хаҗиәхмәтов (1997–99), И.Ш.*Фәрдиев* (1999–2010), И.Х.Гайфуллин (2010 нан).

Ш.у.к. *Электр энергетикасы*.

Чыг.: История энергетики Татарстана (1920–2000 гг.): Док. и материалы. К., 2001.

*Әд.:* Мы и время: Очерки из истории энергетической системы Татарстана. Чебоксары. 2002; Татарстан: Спец. вып., посвящ. ОАО «Татэнерго». 2002. № 12.

**«ТАТЭНЕРГОСТРО́Й»,** Татарстандагы иң зур төзелеш оешмаларының берсе, Түбән Кама шәһәрендәге сәнәгать, энергетика, гражданлык төзелешләренең ген. подрядчысы. «Т.» 1963 елда «Лениногорскнефтестрой» тресты бүлекчәләре һәм Зәй ГРЭСы төзелеш идарәсе җирлегендә СССР Энергетика һәм электрлаштыру министрлыгының Татарстан «Т.» төзелеш-монтаж тресты буларак оештырыла. 1971 дән — «Т.» төзелеш идарәсе, 1988 дән — «Т.» төзелеш-монтаж берләшмәсе, 1990 нан — «Т.» дәүләт төзелеш-сәнәгать берләшмәсе, 1996 дан — «Т.» АҖ. 2003 тән «Камаглавстрой» идарәче компаниясе» («Камаглавстрой ИК») АҖ. Башта пр-тиенең төп бурычы Түбән Кама нефть химиясе комб-ты, Зәй ГРЭСы һәм Чаллы күзәнәкле бетон з-ды төзүдән гыйбарәт була; иң элек аның составына 7 төзелеш-монтажлау идарәсе керә. Алга таба ул генподряд (Түбән Кама шәһәрендәге йортлар төзү комб-ты, «Химстрой-1», «Химстрой-2», «Жилстрой», «Теплоэнергострой», «Промстрой» трестлары, Мамадыш һәм Түбән Кама шәһәрләрендәге күчмә механикалаштырылган колонналар) һәм субподряд (Түбән Камадагы «Отделстрой», «Строймеханизация» һәм «Спецстрой» трестлары) төзелеш-монтаж бүлекчәләрен, төзелеш материаллары сәнәгате пр-тиеләрен (тимер-бетон эшләнмәләр һәм металл конструкцияләр, эре панельле йортлар салу, кирпеч з-длары, агач эшкәртү комб-ты), ярдәмче транспорт, энергетика бүлекчәләрен эченә ала, 14 меңнән артык кеше эшләгән зур төзелеш комплексына әверелә.

Нефть химиясе комплексы куәтләре төзелешенең комплекслы программасы эшләнә. Аның аеруча мөһим мәсьәлә булуы сәбәпле, ВЛКСМ ҮК төзелешне Бөтенсоюз удар комсомол төзелеше дип белдерә. Эш күләмнәренең зурлыгы һәм башкару вакытының кыскалыгы объектларны тиз араларда куллануга тапшыру өчен принципиаль рәвештә яңа чишелешләр, төзелешне оештыруда алдынгы, аеруча уңышлы алымнар куллануны таләп итә. Эш тәүлек әйләнәсе, барлык объектларда да бер үк вакытта бара. Бирелә беренче



«Камаглавстрой» идарәче компаниясе» АҖ. Административ бина.

тапкыр алга таба илнең башка төзелешләрендә киң кулланыш тапкан (җиһаздагы анкер болтларны тимер бетонга эпоксид җилеме б-н беркетү, бетон тротуар плитәсен әзерләү өчен резин опалубка, яңа җәелгән бетонлы җылылык б-н эшкәртү өчен полимер термоактив элементлардан әзерләнгән җәймә, җыелма тимер бетон суыткыч торбалар, фасад өчен бизәкле кызыл кирпеч) бик күп яңа технологияләр, конструкцияләр һәм материаллар үзләштерелә. «Т.»ның беренче эшләгән елларында ук 36 мең $м^2$ торак, 140 урынлы балалар бакчасы, 960 урынлы мәктәп, пионер лагере, «Кама» кибете файдалануга тапшырыла. 1980 еллар башына Түбән Камада ел саен 160 мең $м^2$ чамасы уңайлы торак сафка баса. Нәтиҗәдә, «Т.» эреләндерелгән, югары җитештерүчән җиһазлар кулланылган зур егәрлекле нефть химиясе пр-тиесе комплексын, ш.у. сәнәгать пр-тиеләре шәһәр читеннән чыгарылган һәм торак кварталлардан 6 *км* киңлектәге урман сан. зонасы б-н аерып алынган яңа типтагы шәһәр төзелешен кызу темплар б-н тәэмин итеп тора. «Т.» эшчәнлеге елларында «*Түбәнкаманефтехим*», «*Түбәнкамашин*», «Түбәнкаматехуглерод», «Түбән Кама нефть эшкәртү заводы» (хәзер «ТАИФ-ТК»), «*Түбән Кама электр җылылык үзәкләре*», «*Менделеевазот*» минераль ашламалар җитештерү АҖ, Чистай шәһәрендәге сөт комб-ты, «*Камэнергостройпром*» АҖ һәм

шәхси милек төзелеш индустриясе базалары; 250 мең яшәүчегә исәпләнгән Түбән Кама шәһәре (торак фонды тиешле инфраструктура б-н тәэмин ителгән); Менделеев, Чистай, Мамадыш, Казан (*Тузган торакны бетерү программасы* буенча), Чаллы, Алабуга, Әлмәт шәһәрләрендәге торак йортлар, социаль-мәдәни һәм көнкүреш объектлары тулысынча төзелеп бетә; магистраль автомобиль юллары, элемтә, авыл, ш.и. респ-ка районнарындагы тораклар, Татар атом электр станциясе объектлары корыла; Әрмәнстан ССРда 1988 елдагы җир тетрәүдән соң торгызу эшләре алып барыла.

1990 елларның 2 нче яртысында торак (торак төзелешен сафка бастыру күләме 3 тапкырга диярлек кими) һәм сәнәгать төзелешендәге заказларның кискен кыскаруы, башка икътисади кыенлыклар нәтиҗәсендә «Т.»ның финанс хәле сизелерлек начарлана. Банкротлык процедурасын башкарганнан соң һәм арбитраж идарәсе кертелгәннән соң (2002), «Т.» АЖ «Камаглавстрой ИК» АЖ итеп үзгәртелә. 2010 да аңа киң профильле төрле хезмәтләр — уңайлы торак, социаль-мәдәни һәм көнкүреш, нефть химиясе һәм нефть эшкәртү объектлары төзелешләрен, монтажлау, электр кертү, автойөк ташу, төзелеш материаллары җитештерү (эре панельле йортлар төзелеше, металл конструкцияләр, тимер-бетон эшләнмәләр) эшләрен башкаручы 21 ҖЧҖ керә. Махсус техникасы һәм транспорты булган зур паркы бар. Гомуми эшләүчеләр саны 8 мең кешегә якын.

Структур үзгәрешләр төзелеш тизлеген һәм күләмнәрен арттыруга китерә. 2003–09 да «Камаглавстрой ИК» Түбән Камадагы субподряд оешмалары б-н бергә 450 мең $м^2$ дан артык торак төзи, 75 *МВт* егәрлектәге электр энергиясеннән файдаланучы газ турбинасы җайланмасын, «Түбәнкамашин» АҖнең тоташ металлдан эшләнгән кордалы шин з-ды, төзелеш индустриясе базасындагы сәгатенә 16–25 *Гкал·сәг.* егәрлегендәге котельныйны, газ бүлүче станцияне файдалануга тапшыра; 3 нче су күтәрткечнең су чистарту станцияләре һәм су б-н тәэмин итү системалары, шәһәр инженерлык челтәре һәм корылмалары яңартыла. Иң зур нефть химиясе һәм нефть эшкәртү комплексы — «ТАНЕКО» АЖ төзү башкарасы эшләрнең төп объекты булып тора (6,5 меңнән артык кеше эшли). Түбән Кама терр-ясендә торак йортлар комплексы — һәркем өчен аерым, бер катлы йортлар да, 12–13 катлы монолит һәм эре панельле биналар да төзелә. Миңнебай газ эшкәртү з-дының куәтләренә реконструкция ясала һәм яңартыла.

Пр-тие бернichә тапкыр тармак һәм ведомство дипломнары, күчмә байраклар б-н бүләкләнә. Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә, ш.и. Соц. Хезмәт Герое исеменә — 2 кеше, СССР МС бүләгенә — 4, РСФСРның атказ. төзүчесе исеменә — 10, ТАССР, ТРның атказ. төзүчесе исеменә — 77, ТРның атказ. транспорт хезмәткәре исеменә — 5, ТРның атказанган икътисадчысы исеменә — 4, ТРның атказ. энергетигы исеменә — 1, орден һәм медальләргә 1500 дән артык кеше лаек була.

Пр-тие җитәкчеләре: И.В.Ильич (1963), Е.Н.*Королёв* (1963–77), А.А.Болдырев (1977–79), В.П.*Беляев* (1979–94), И.З.Гарифуллин (1994–99), И.М.Низамов (1999–2001), Н.И.Типтяров (201–03), В.И.Самилов (2003 тән).

*Әд.:* Архитектурно-строительный комплекс Республики Татарстан: История, биография, свершения, надежды. К., 2005.

*Н.И.Типтяров, С.Г.Белов.*

**ТА́У ИЛЕ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 40 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шыя елгасы буенда. 2010 елда 286 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1680 нән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Никольский исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1750 елларда Кама казна тимер эшкәртү з-дларына беркетелә; игенчелек, терлек асрау, тимерчелек, йон-тукыма ману, балта эше һәм токарьлык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.И.ндә волость идарәсе урнаша; Никольский чиркәве (1818–23 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1867 дә ачыла), табиблек пункты, 3 тегермән, 12 тимерчелек, 3 май язу һәм 3 йон-тукыма ману йорты, 3 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 8 вак-төяклар кибете була; шимбә базары, ярминкә (9 май, 1 окт., 6 дек.) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3362,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кабык Күпер волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 227 ир-ат; 1859 да — 1288, 1897 дә — 2025, 1908 дә — 1741, 1920 дә — 1816, 1926 да — 1818, 1949 да — 791, 1958 дә — 679, 1970 тә — 389, 1979 да — 379, 1989 да — 331, 2002 дә — 304 кеше.

**ТА́У ИЛЕ́** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 15 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Норма елгасы (Мишәнең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 545 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1602–03 еллардан Бимәр Тау Иле буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Тау Иле-Ходяш исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 2 ярма яргыч, су тегермәне, балавыз әретү йорты, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1705 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Сәләнгеш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 87 ир-ат; 1859 да — 782, 1897 дә — 1166, 1908 дә — 1356, 1920 дә — 1407, 1926 да — 1134, 1949 да — 921, 1958 дә — 698, 1970 тә — 688, 1979 да — 629, 1989 да — 574, 2002 дә — 578 кеше.

**ТА́У ИЛЕ́** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 71 *км* көньяктарак, Тетвель елгасы буенда. 2010 елда 161 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Клуб, китапханә. 1710–11 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.И.ндә чиркәү-приход мәктәбе (1885 тә ачыла), тегермән, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1308 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Зирекле волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә, 1984 нең 3 июленнән — Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1782 дә — 62 ир-ат; 1859 да — 319, 1897 дә — 650, 1908 дә — 681, 1920 дә — 896, 1926 да — 518, 1938 дә — 422, 1949 да — 530, 1958 дә — 412, 1970 тә — 405, 1979 да — 253, 1989 да — 188, 2002 дә — 158 кеше.

**ТА́У ИЛЕ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 31 *км* көньяк-көнбатыштарак, Әрә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 111 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1641 гә кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Товлина буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1880 дә төзелә), мәдрәсә, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 362 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 73 ир-ат; 1859 да — 227, 1897 дә — 347, 1908 дә — 410, 1920 дә — 460, 1926 да — 373, 1938 дә — 380, 1949 да — 277, 1958 дә — 232, 1970 тә — 300, 1979 да — 225, 1989 да — 143, 2002 дә — 120 кеше. Т.И. янында *Тау Иле шәһәрлеге* урнашкан.

**ТА́У ИЛЕ́ ШӘҺӘРЛЕГЕ́**, археол. истәлек; Яшел Үзән р-нының Тау иле авылы янындагы урта гасырлар (13–14 йөзләрнең 2 нче яртысы) болгар торулыгы. 19 йөздән билгеле; 1877 елда С.М.Шпилевский, 1898 дә В.Л.Борисов, 1909 да Г.Н.Әхмәров, 1950 дә СССР ФА Казан ф-лы археол. экспедициясе, 1967 дә Татарстан археол. экспедициясе, 1990 да СССР ФА Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты археологлары һ.б. тарафыннан өйрәнелә. К.Насыйри «Тау иле» сүзенең этимологиясен «Тау иле» дигән тарихи атамага тиңләштерә. Т.и.ш.нең мәйданы 0,68 *га*; Зөя елгасы бассейнына кергән исемсез елгачык борыны террасасында (биеклеге 25–30 *м*)

урнашкан. Шәһәрлек терр-ясе төньяктан ике ур һәм алар арасындагы чокыр (нығытмаларның озынлыгы 100 *м* чамасы; тышкы урның биеклеге 0,5–1 *м*; киңлеге 6–7 *м*; эчке урның биеклеге 1 *м*, киңлеге 8 *м*; чокырның тирәнлеге 1,5 *м*, киңлеге 7–8 *м*) б-н саклана. Т.и.ш.ндә 14 йөз акчалары, сугыш кораллары, Имәнкискә һәм Болгар культураларына нисбәтле керәч, көнкүреш әйберләре табыла. Шәһәрлек янында ш.у. болгар авыллыгы һәм 13–14 йөзләр мөселман зираты булуы ачыклана.

*Әд.:* Шпилевский С.М. Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; Фахрутдинов Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и её территория. К., 1975; Губайдуллин А.М. Фортификация городищ Волжской Булгарии. К., 2002.

*А.М.Гобәйдуллин.*

**ТА́У НАРАТЛЫГЫ́**, табигать истәлеге, Югары Ослан р-ны терр-ясендә (Патрикеево авылыннан төньяк-көнбатыштарак). 1972 елда билгеләнә. Мәйданы 70 *га*. Зөя елгасы үзәнендәге көньяк-көнбатыш экспозициянең Пермь карбонаты утырмаларыннан торучы уңъяк текә сөзәклеген били. Тау наратлыгы дип аталучы зур булмаган нарат урманы участогы яфраклы урман эчендә мергель утырмаларында урнашкан. Биредә үсүче кайбер агачларга 200 яшь, кәүсә әйләнәсе 1 *м* дан артыграк. Ташлы субстратта үскән наратлар танылган геоботаник Д.И.Литвинов тарафыннан билгеләнә (1891), ул нарат урманнарын башка ылыслы бергәлекләр б-н беррәттән дүртенчел чорга кадәр тау шартларында формалашкан дип исәпли. Хәзерге геоботаникада тау нараты гади наратның аерым бер төрчәсе буларак карала, еш кына акбур нараты (Pinus sylvestris var. cretacea) дип йөртелә. Ылысларының кыскарак, күркәләренең озынча-түгәрәк булуы, тәңкәләренең формасы, салынкы өлгергән күркәләре б-н аерылып тора. Т.н.нда ш.у. юкә, имән, өрәңге үсә. Урман эчендә имәнлекләргә хас агач-куаклар: чикләвек, сөялле кабар, урман зелпесе, кошкунмас агач таралган. Үлән капламында киң яфраклы һәм катнаш урман төрләре үсә: өч аерчалы күгелҗем ут, оеш кыңгырау чәчәк, нут мәче борчагы, ромашкасыман кашкарый, буяулы сырмавык, чын йогырт, миләүшә, күп чәчәкле һәм дарулы сөләйман мөһере, бер яклы рамши уты һ.б. Сәхләбчәләр семьялыгыннан ТРның Кызыл китабына кертелгән вәкилләре — чын башмакчәчәк, куе кызыл йод үләне, черки шәрә бизлеге, кызыл серкәбаш очрый. Объект фәнни әһәмияткә ия.

*Әд.:* Памятники природы Татарии. К., 1977.



Тау наратлыгы.

**ТА́У ТОКЫМНАРЫ́**, мөстәкыйль геол. җисемнәр буларак Җирнең литосферасын төзүче табигый минераль агрегатлар. Гадәттә, Т.т.на каты җисемнәрне генә кертәләр, киңрәк алганда аларга ш.у. су, нефть һәм табигый газлар да керә. Т.т. Җир төркеме планеталарының өске тышчасын, ш.у. Ай һәм астероидларны төзиләр. «Т.т.» терминын 1798 елда рус геологы В.М.Севергин кертә. Т.т.н өйрәнүче фәннәр — *петрография, литология, петрофизика*, Т.т. физикасы. Минераль бөртекләр яки кисәкле өлешләрнең үзара урнашуы һәм бүленеше Т.т.ның структурасын һәм текстоникасын төзи, мөһим диагностик билге булып тора. Бер минералдан яисә минераллар комплексыннан торырга мөмкин. Токым барлыкка китерүче 50 гә якын минерал билгеле (алар барлыгы 3000 нән артык). Килеп чыгышы буенча утырма, магматик һәм метаморфик Т.т.на бүленә. Утырма токымнар җир кабыгы күләменең 10% чамасын төзиләр, Җир өслегенең якынча 75 % ын билиләр. Магматик (Җир өстенә чыккан) Т.т. Җир асты тирәнлекләреннән чыккан эремәнең (магманың) суынып катуы нәтиҗәсендә барлыкка киләләр, интрузивларга (тирәндә катып калганнарга) — гранит, сиенит һ.б. һәм эффузивларга (җир өстенә агып чыкканнарга) — базальт, андезит һ.б. бүленәләр. Метаморфик Т.т. — *гнейс*, амфиболит һ.б. — утырма һәм магматик Т.т. үзгәрүе (метаморфлашу) нәтиҗәсендә хасил булалар. Тау эшләре объекты буларак Т.т. кыя ташлы, ярымкыя ташлы, тыгыз, йомшак, сибелмә һәм җимерелгән токымнарга бүленә. ТР терр-ясендә Т.т.ның 50 гә якын төре билгеле. Утырма тышлыкны, нигездә, утырма Т.т.: вакланган (*ком, чуерташ* һ.б.), балчыксыл (*балчык, мергель* һ.б.), хемоген (*доломит, известьле туф*), биохемоген (*фосфоритлар*), органоген (*гипс, казылма күмерләр, известьташ* һ.б.) тәшкил итә. Тирәндә, кристаллик нигездә, магматик һәм метаморфик Т.т. үсеш алган. Т.т.ның күпчелеге халык хуҗалыгында файдаланыла.

*Әд.:* Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

*Ю.В.Сементовский.*

**ТАУ ЧЫПЧЫКЛАРЫ́** (Fringillidae), чыпчыксыманнар отрядыннан кошлар семьялыгы. Дөнья фаунасында якынча 133 төре бар, Австралия һәм аңа якын утраулардан кала бөтен Җир шарында таралганнар. ТР терр-ясендә 14 төре бар. *Купшыл, балан чыпчыгы* (карабүрек), чыршы чукыры (Loxia curvirostra) ел дәвамында яши. Яшел чыпчык (Chloris chloris), *кызылтүш, сары чыпчык*, гади ясмык чыпчыгы (Carpodacus erythrinus) һ.б. оя кору өчен очып киләләр. Корташар кош (Pinicola enucieator), пуночка (Plectrophenax nivalis), гади кыр чыпчыгы (Acanthis flammea) кышларга очып киләләр. Юрок (Fringilla montifringilla) очып уза. Гәүдә озынлыгы 10–22 *см*, каурый капламы тыгыз. Күп кенә төрләрнең аталары аналарына караганда ачыграк төстә; кызыл, сары һәм яшел төсләр өстенлек итә. Томшыгы төрле зурлыкта һәм формада. Койрыгы уемтылы, туры яки очы аз гына түгәрәкләнгән. Моногамнар. Аерым пар булып оялыйлар. Агачларда, куакларда ачык, тирән төпле оялар ясыйлар. 4–6 чуар йомырка салалар. Т.ч.ның барлык вәкилләре, нигездә, үсемлек азык б-н, фәкать балаларын ашату чорында гына бөҗәкләр б-н тукланалар. Чүп үләннәре орлыкларын ашап файда китерәләр.

**«ТА́У ЭШЕ́ ТЕ́ХНИКАСЫ»**, айлык тармак техник журналы. СССР Авыр сәнәгать халык комис-тының Техника-пропаганда секторы, нәшриятларның бөтенсоюз фәнни-техник берләшмәсе органы. 1932 елның октябреннән 1937 нең декабренә кадәр Мәскәүдә татар телендә нәшер ителә, барысы 57 саны чыга. Төрле еллардагы мөхәррирләре — Г.Төхвәтуллин, С.Садыйков, Р.Яһүдин, С.Шәфиев. Редакция б-н тау эше галимнәре, инженер-белгечләр: В.Беликов, Х.Вәлиев, З.Ганиев, П.Герасимов, Ф.Горшков, И.Губкин, А.Зозуля, К.Ибәтуллин, К.Ибраһим, И.Измайлов, Х.Кадермәтов, И.Кайбышев, М.Кравцов, К.Насыйбуллаев, Ф.Насыйров, А.Пущин, Х.Ситдыйков, Н.Шәрифҗанов һ.б. хезмәттәшлек итә. Редакциянең төп көче күмер, тау токымнары һәм нефть сәнәгатендә эшләүче татар эшчеләрен һәм белгечләрен мобилизацияләүгә, аларның техник белемен күтәрүгә, житештерү планнарын үтәүгә, алдынгы шахталар, промыселлар, аерым бригадаларның тәҗрибә алмашуын оештыруга юнәлдерелә. Журнал материалларында СССРда индустрияләштерү чорында татар эшчеләренең авыр сәнәгатьне үстерүгә керткән өлеше турында күп мәгълүматлар урын ала. Эшне механикалаштыру, җир асты байлыкларын чыгару системасын яхшырту, җитештерүне оештыру мәсьәләләре карала; чит ил тәҗрибәсе актив яктыртыла. Әйдәп баручы техник белгечләрнең мәкаләләрендә җитештерү процессларын, машина һәм механизмнар сыйфатын камилләштерү буенча гамәли тәкъдимнәр, аңлатма схемалар һәм рәсемнәр бирелә. Журнал төсле матур рәсемнәр б-н бизәлә. Алдынгы шахталар, промыселлар, рудникларның, Донбасс, Урал, Кузбасс, Бакудагы татар эшчеләренең күпсанлы фоторәсемнәре басыла. Журнал милли телләрдәге совет матбугатын үзәктән ерагайту сәясәтен үткәрү барышында ябыла.

*Т.М.Насыйров.*

**«ТА́У ЭШЧЕСЕ́»**, газета. Украина КП(б) ҮК каршындагы Татар-башкорт секцияләренең Үзәк бюросы органы. 1921 елда Харьков шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Донбасс тау эшләре сәнәгате пр-тиеләрендә хезмәт куючы татар эшчеләре өчен басыла.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

**ТА́У ЯГЫ́**, 16 йөзнең 2 нче яртысында элекке Казан ханлыгы биләмәсенең төньяк-көнбатыш өлеше. Үзәге — Зөя шәһәре. Т.я.нда яшәүчеләрне «тау ягы кешеләре» дип тә йөрткәннәр. Башлыча, чуаш, мари, мордвалар яшәгән. Т.я. Казанны яулап алганда Иван IV гаскәрләренә ярдәм итә, 1550 һәм 1570–80 елларда Идел елгасының сулъяк ярында халык чуалышларын бастырганда патша хакимиятенә терәк була. Т.я. терр-ясе Зөя өязенә керә. *Д.А.Мостафина.*

**ТАУАСТЫ́ БАЙЛА́Р** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 8 *км* төньяк-көнбатыштарак, Түбән Кама сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 417 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1851 дә Иске Байлар авылыннан күченүчеләр нигез сала. Халкы асабалар катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Б.да мәчет (1890–91 дә төзелә), мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1556 дис. тәшкил итә. 1970 елларда Түбән Кама сусаклагычы төзелгәнлектән, авыл 2 *км* га көньяккарак күчерелә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Күзкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1859 да — 281, 1870 тә — 287, 1884 тә — 427, 1897 дә — 594, 1906 да — 713, 1920 дә — 873, 1926 да — 897, 1938 дә — 919, 1949 да — 628, 1958 дә — 587, 1970 тә — 622, 1979 да — 498, 1989 да — 431, 2002 дә — 466 кеше.

**ТАУАСТЫ́ ТӘКЕРМӘ́Н** (Түбән Тәкермән) авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 28 *км* көнбатыштарак, Ургыды елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 344 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб, китапханә. 1748 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Тәкермән исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чабата үрү һ.б. һөнәрләр б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. Т.Т.дәге мәчет беренче тапкыр 1807 дә телгә алына. 20 йөз башында 2 мәчет, 3 мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4482 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Күзкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 162, 1859 да — 928, 1870 тә — 1048, 1884 тә — 1325, 1897 дә — 1515, 1906 да — 1770, 1920 дә — 1752, 1926 да — 1123, 1938 дә — 1246, 1949 да — 1023, 1958 дә — 846, 1970 тә — 919, 1979 да — 730, 1989 да — 434, 2002 дә — 367 кеше.

**ТАУЗА́Р** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 10 *км* көнбатыштарак, Шушма елгасы буенда. 2010 елда 184 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — игкә терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәчет. 1615–16 еллардан Тоусар буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Тавзарова исеме б-н мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чыпта-кап сугу, сарык тиресе эшкәртү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 653,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1678 дә — 56, 1745 тә — 58, 1762 дә — 71, 1834 тә — 129 ир-ат; 1859 да — 344, 1878 дә — 395, 1897 дә — 472, 1908 дә — 490, 1920 дә — 475, 1926 да — 455, 1938 дә — 472, 1949 да — 247, 1958 дә — 277, 1970 тә — 234, 1979 да — 189, 1989 да — 187, 2002 дә — 165 кеше.

*Әд.:* З ы я т д и н о в Б.Ш. Мәгърифәтле Таузар иле. К., 2004.

**ТАУЛА́Р** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 48 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Шомбыт елгасы буенда. 2010 елда 176 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1680 нән Пустошь Шимбутбаш буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Чаллы исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 669,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Шомырбаш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 59 ир-ат; 1859 да — 286, 1897 дә — 549, 1908 дә — 585, 1920 дә — 592, 1926 да — 612, 1938 дә — 780, 1949 да — 516, 1958 дә — 514, 1970 тә — 455, 1989 да — 242, 2002 дә — 212 кеше.

**ТАУЛА́Р** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 35 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Игәт елгасы буенда. 2010 елда 109 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1702 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек, тәгәрмәч ясау, итек басу, чабата үрү, олаучылык, сәүдә б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында Т.да мәчет (1814 тән билгеле), мәктәп, Халык мәгарифе министрлыгы уч-щесе, күмәч пешерү йорты, 2 бакалея кибете, сатып алынган ашлыкны саклау келәте була; сишәмбе базары эшли. 1913 тә авыл җәмәгатенең имана җире 1185 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Күзкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1834 тә — 69 ир-ат; 1859 да — 509, 1870 тә — 502, 1884 тә — 639, 1897 дә — 602, 1906 да — 770, 1913 тә — 762, 1920 дә — 934, 1926 да — 589, 1938 дә — 444, 1949 да — 386, 1958 дә — 286, 1970 тә — 198, 1979 да — 156, 1989 да — 93, 2002 дә — 97 кеше.

**ТАУЛЫ́ ДӨРЕ́Ш** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 26 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Инеш елгасы (Игәнәнең сул кушылдыгы) бассейнында урнашкан. 2010 елда 107 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Дөреш исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, мәчет, мәктәп, 2 су тегермәне эшли. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Язикәү волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Сарман, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1834 тә — 273, 1859 да — 508, 1870 тә — 608, 1897 дә — 847, 1920 дә — 756, 1926 да — 419, 1938 дә — 492, 1949 да — 370, 1958 дә — 300, 1970 тә — 225, 1979 да — 165, 1989 да — 108, 2002 дә — 114 кеше.

**ТАУЛЫ́К** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 35 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Чаллы–Сарман автомобиль юлы буенда. 2010 елда 155 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, умартачылык. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1710–11 еллардан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, ашлык саклау-сату һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1101 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Язикәү волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Сарман, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1816 да — 116 ир-ат; 1959 да — 326, 1870 тә — 597, 1897 дә — 742, 1906 да — 791, 1926 да — 460, 1970 тә — 296, 1979 да — 215, 1989 да — 128, 2002 дә — 147 кеше.

**ТАХИННА́Р** (Tachinidae), ике канатлылар отрядыннан бөҗәкләр семьялыгы. Элегрәк каллифоридлар семьялыгына кертелде, бу

семьялык вәкилләреннән личинкаларының башка бөҗәк һәм күбаяклыларда паразитлык итүләре б-н аерыла. Озынлыгы 3–20 *мм.* Тышкы кыяфәте үзенчәлекле: күкрәкләрендәге һәм корсакларындагы каты озын төкчәләре аларны керпегә охшата. 5 меңнән артык төре билгеле; Россиядә — 1 меңгә якын, Татарстан терр-ясендә төгәл саны билгеләнмәгән. Киң таралган төре — җирән керпечебен (Tachina fera), аның личинкалары кузы күбәләге, дулкынча, ябалакчык гусеницаларында паразитлык итәләр. Т.ның олы затлары чәчәк нектары б-н туеналар һәм кеше торагына бәйле түгелләр. Күкәйләрен корбанына яки аның янына (бу очракта личинка корбанын үзе эзләп таба) сала. Личинкалар 3 тәүлектән 2 атнага кадәр, курчаклары 8 тәүлектән 6 атнага кадәр үсә. Личинка һәм курчаклары кышлый. Күпчелек Т. а.х. һәм урман культураларын зарарлаучы бөҗәкләрнең паразитлары буларак файдалы. *Р.М.Зелеев.*

**«ТАҺИ́Р БЕЛӘ́Н ЗӨҺРӘ́»**, гомумтөрки лиро-эпик китап дастаны. Татарларда, башкорт, казакъ, үзбәкләрдә һ.б. төрки халыкларда таралган. Алтын Урда чорына карый. Эчтәлеге һәм сәнгать үзенчәлекләре ягыннан «*Кузы Күрпәч белән Баянсылу*» дастанына якын. Дастаннарга хас традицион фаҗигале мәхәббәт сюжетына нигезләнгән. Яшьләр — падишаһ кызы Зөһрә һәм вәзир улы Таһир — кечкенәдән бер-берсен яраталар, әмма Зөһрәнең әти-әнисе аларның кушылуына каршы килә. Таһир күргән төш (традицион фольклор жанры) еғеткә зур кайгылар киләчәген хәбәр итә, бу шулай була да. Падишаһ Таһирны җәзаларга дип ике тапкыр әмер бирә, әмма Таһир котыла, качып кире кайта һәм сөйгәне б-н очраша. Зөһрәгә гашыйк гарәп бу очрашуларны күзәтеп падишаһка җиткерә. Егетне өченче тапкыр тотып алалар һәм мәйданда җәзалыйлар. Җәзаланган сөйгәнен күреп, Зөһрә үлә, ә гарәп үз-үзенә кул сала. Кызның кабере́ндә — матур ак чәчәк, Таһирнекендә — ал чәчәк, ә гарәп каберендә ике чәчәкнең бер-берсенә үрелеп үсүенә мөмкинлек бирмәүче кара чәнечке үсеп чыга. Беренче тапкыр дастан вариантларының берсе Радлов тарафыннан Тубыл татарларыннан язып алына һәм «Көньяк Себердә һәм Җунгар далаларында яшәүче төрки кабиләләрнең халык әдәбияты үрнәкләре» («Образцы народной литературы тюркских племён, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи», 1872, ч. 4) хезмәтендә басылып чыга. Башка вариантлары 20 йөзнең төрле елларында Татарстан, Мордва респ-калары районнарында, Омск, Пермь, Чиләбе һәм Төмән өлкәләрендә язып алына. 1917 дә Ә.Уразаев-Кормаши тарафыннан казакъ һәм нугай текстларына нигезләнеп («Кыйсса-и Таһир илә Зөһрә») нәшер ителә. 20 йөз башында 20 тапкырдан артык кабат басылып чыга һәм киң танылу ала. ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының фольклор фондында һәм кулъязмалар мирасханәсендә дастанның 11 варианты бар. Бу сюжетка нигезләнеп, Ф.Бурнаш «Таһир-Зөһрә» трагедиясен яза (1917). Әлеге фаҗигале мәхәббәткә шул ук исемдәге татар халык җыры (1950 еллар) багышланган.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Дастаннар. К., 1984.
*Ф.И.Урманчеев.*

**ТАҺИРҖА́НОВ** Габдрахман Таһир улы (7.2.1907, Казан губ., Тәтеш өязе Морзалар а. — 18.12.1983, Ленинград), әдәбиятчы-шәркыятьче галим, филол. фән. д-ры (1970), проф. (1972). 1941 елда Ленинград ун-тын тәмамлый. 1946 га кадәр — Мәскәү, Казан, Ташкент, Дүшәмбе югары уку йортларында, 1946–83 тә Ленинград ун-тының шәрекъ ф-тында укыта, бер үк вакытта, 1946–50 дә, СССР ФАнең Көнчыгышны өйрәнү ин-тында эшли. Т. — фарсы-таҗик, гарәп һәм төрки әдәбиятлар тарихын чагыштырма-типологик планда өйрәнүче, текстолог. 12–15 йөзләр төрки-татар әдәбиятына, аның гарәп һәм фарсы әдәбиятлары б-н элемтәләренә багышланган хезмәтләрендә әдәби күренешләргә герменевтик һәм тарихи-әдәби карашлар бердәмлеген раслый (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Фирдәүси һәм Шәйәд Хәмзәнең «Йосыф һәм Зөләйха», Котб һәм Низаминың «Хөсрәү вә Ширин» поэмаларын чагыштырып өйрәнү). Фирдәүсинең «Шаһнамә» әсәренең фәнни-тәнкыйди текстын төзүче, Ленинград дәүләт университеты китапханәсенең Көнчыгыш бүлегендәге таҗик һәм фарсы кулъязмаларының тасвирламасы авторы. Т. ш.у. Кол Гали, Котб, Әмир Хөсрәү Дәхләви, Низами Ганҗәви, Гаттар, Әбүгалисина, Рудаки, Әшрәф Гыйләни, Шәмси Фәхри Исфаһани һ.б. иҗатларына, «Манас» кыргыз эпосы тарихы, болгар-татар этногенезы, болгарларның мәдәнияте һәм әдәбияты, әзәрбайҗан поэзиясе тарихына, үзбәк һәм төрек әдәбиятлары ядкәрләренә һ.б. багышланган хезмәтләр яза. Т.ның фарсы телендә язылган монографияләре һәм мәкаләләре Иранда, Әфганстанда нәшер ителә.

Х е з м.: Тарихтан әдәбиятка. К., 1979; Собрание историй «Маджму'ат-таварих», Л., 1960; Описание таджикских и персидских рукописей Восточного отдела библиотеки ЛГУ. Т. 1. История, биография, география. Л., 1962; Список таджикских, персидских и тюркских рукописей Восточного отдела библиотеки ЛГУ: Продолжение списков К.Г.Залемана и А.А.Ромаскевича. М., 1967; Рудаки. Жизнь и творчество: История изучения. Л., 1968.

*Әд.:* Х и с а м о в Н. Хәтер сагында. К., 2004; Б о г о л ю б о в М.Н. Памяти А.Т.Тагирджанова // Вестн. Ленингр. ун-та. 1984.№ 14, вып. 3.
*Ә.М.Шәрипов.*

**ТАҺИ́РОВ** Афзал Мөхетдин улы (25.10.1890, Самара губ., Бөгелмә өязе Габдрахман а. — 27.9.1937, Мәскәү), язучы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе. 1905–08 елларда Казан мәдрәсәсендә, 1910–11 дә «Хөсәения» (Оренбург) мәдрәсәсендә белем ала. 1911–17 дә патша армиясендә хезмәт итә. Беренче бөтендөнья, Гражданнар сугышларында катнаша. 1918–21 дә Оренбург губерна башкарма ком-ты, губерна халык мәгарифе бүлеге әгъзасы, «*Юксыллар сүзе*» г-тасы мөхәррире, Көнчыгыш фронтның 1нче армия сәяси мәктәбе җитәкчесе. 1921–25 тә Үзбәкстанда яши, РКП(б)ның Сәмәркәнд өлкә ком-тында агитация-пропаганда бүлеген, өлкә халык мәгарифе бүлеген, ВКП(б)ның Хива өлкә ком-тында агитация-пропаганда бүлеген җитәкли, «Инкилоб кояшы» г-тасы мөхәррире, ВКП(б) Үзәк контроль комиссиясе рәисе булып эшли. Коммунистлар академиясе каршындагы курсларны тәмамлагач (Мәскәү, 1927), ВКП(б)ның Башкортстан өлкә контроль комиссиясендә партия коллегиясе секретаре урынбасары итеп билгеләнә. 1931–37 дә Башкортстан ҮБК рәисе, Бөтенсоюз ҮБК Президиумы әгъзасы, Башкортстан АССР Язучылар берлеге рәисе, бер үк вакытта, 1936 дан, Башкортстан Тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. 1937 дә репрессияләнә (к. «*Миллэтчеләрнең контрреволюцион-фетнәчел оешмасы» эше*), атарга хөкем ителә. Үлгәннән соң аклана.

1905–07 елгы рев-ция елларында яза башлый. «Бичура» (1907) исемле беренче пьесасы мәдрәсә шәкертләре б-н уйнала. Иҗатының башлангыч чорында мәгърифәтчелек идеяләрен алга сөрә. Әсәрләрендә ул вакытта яшәп килгән иҗтимагый мөнәсәбәтләрне үзгәртергә, социаль һәм милли изүгә каршы, хатын-кызлар хокуклары өчен көрәшкә чакыра: «Ятим малай» (1907), «Сатылган кызлар» (1908), «Мазлумалар» (1912), «Әтрәгәләмдәр» (Өфө, 1916) повестьлары; «Ач һәм ялангачлар» (1918), «Килде-китте» (1918) пьесалары. Алга таба язучының иҗат ысулы тәнкыйди реализмга таба үзгәреш кичерә, әсәрләренең социаль юнәлеше көчәя. Т.ның совет чоры иҗаты «Кияү белән кәләш» (1924), «Уеннан уймак» (1924), «Динчеләр һәм динсезләр» (1924), бер пәрдәле «Күчү чорында» (1921), «Үрнәк» (1931), «Алатау» (1936) пьесаларыннан гыйбарәт. Башка замандашлары кебек үк, Т. вульгар социологизм йогынтысын кичерә. Бу йогынты персонажларының социаль чыгышлары б-н нык кызыксынуында чагыла. Аның әсәрләренең төп геройлары — сыйнфый көрәштә чыныккан яңа тормыш төзүчеләр: «Ил өреккәндә» (1912), «Беренче көннәр» (1927), «Ташкын дәрья тармакларында» (1928) хикәяләре; «Солдатлар» (1932), «Кызылгвардеецтар» (Өфө, 1935), «Кызылармеецтар» (Өфө, 1937) романнары. Иҗатының шактый өлеше тарихи вакыйгаларга багышлана: Казан ханлыгының яулап алынуына, Е.И.Пугачёв күтәрелешенә: «Янгура» (1922) пьесасы, «Ямәлкә тавы» (1927) повесте һ.б. Т. — татар производство прозасын тудыручыларның берсе: «Иген фабригы» (1930), «Комсомол» (1931), «Штурвалчы» (1931), «Машиналар каны» (1932) повестьлары, «Завод» пьесасы (1929) авторы. Кызыл Байрак һәм Харәзем Республикасы Хезмәт орденнары б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 2008; Әсәрҙәр: 3 томда. Өфө, 1958–59.

*Әд.:* Б ә д р е т д и н о в Р. Каһәрле еллар корбаны. К., 2010. *Р.Ф.Бәдретдинов.*

**ТАҺИ́РОВ** Вартан Рифгать улы (3.5.1952, Казан), поляр тикшерүче, кояш-җир физикасы өлкәсе галиме. Ленинград ун-тын тәмамлый (1975). РФАнең Кола фәнни үзәге Поляр геофизика ин-тында (Мурманск өлкәсе Апатиты ш.) эшли. 2005 тән ТР Сәүдә-сәнәгать палатасында эшли (тәрҗемәче). 23 нче совет Антарктика экспедициясендә (Мирный станциясе, 1978–79), Франц-Иосиф җиренә (Хейса утравындагы Э.Т.Кренкель исем. обсерватория, 1987–88), Шпицберген утра-

вына (Баренцбург ш., 1988–89) оештырылган һ.б. экспедицияләрдә, Көнбатыш Европа һәм АКШ илләре терр-яләрендә поляр балкышларны өйрәнү буенча халыкара экспериментларда катнаша. Хезмәтләре поляр балкыш физикасына һәм атмосферада башка оптик күренешләрне өйрәнүгә карый. Т. поляр балкышларның факел структурасын һәм пульсацияләнүче формаларының табигатен, куәтле ракеталар җибәргәндә атмосферада оптик эффектларны ачыклый. Америка геофизика союзы әгъзасы (1997).

Х е з м.: О происхождении пульсирующих авроральных пятен // Геомагнетизм и аэрономия. 1986. Т. 26, вып. 4; О факельных структурах полярных сияний // Геомагнетизм и аэрономия. 1991. Т. 31, вып. 1 (автордаш); Auroral torch structures: results of optical observations // Journal of Atmospheric and Terrestrial Physics. 1993. V. 55, № 14; Atmospheric optical phenomena caused by powerful rocket launches // Journal of Spacecraft and Rockets (JSR). 2000. V. 37, № 6 (автордаш).

**ТАҺИ́РОВ** Гай (Гайнулла) Хаҗи улы (27.12.1906, Томск губ., Томск өязе Анжерка станциясе, хәзер Кемерово өлкәсенең Анжеро-Судженск ш. — 16.9.1995, Казан), балет артисты, балетмейстер, педагог, ТАССРның халык артисты (1979). 1928 елда — Татар театр техникумын, 1929 да — Казанда Дәүләт балет студиясен, 1938 дә Мәскәү хореография техникумын (педагоглары — А.Н.Чекрыгин, А.М.Монахов, П.А.Гусев) тәмамлый. 1928–33 тә Татар акад. драма театрында балет артисты һәм балетмейстер, 1938–52 дә Татар опера һәм балет театрында балетмейстер, баш балетмейстр, 1952–70 тә ТАССРның Дәүләт җыр һәм бию ансамблендә балетмейстер. 1972–84 тә Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тында халык биюе дәресләре алып бара. Татар акад. театрында Т. 35 муз.-драматик спектакльнең, ш.и. С.Сәйдәшев музыкасына уйналган «Зәңгәр шәл», «Наёмщик», «Казан сөлгесе», «Галиябану», «Ил», «Кандыр буе» спектакльләренең хореография өлешен куя. Татар опера һәм балет театрында «Файдасыз саклык» («Тщетная предосторожность», П.Гертель; 1939), «Яшьләр ял итә» («Молодёжь на отдыхе», А.Ключарёв музыкасы; 1944), «Шүрәле» (Ф.Яруллин, 1945, Л.А.Жуков б-н берлектә), «Кызыл мәк» («Красный мак», Р.Глиэр; 1950) балетларын; «Фауст» (Ш.Гуно), «Кармен» (Ж.Бизе), «Кенәз Игорь» (А.Бородин), «Качкын», «Алтынчәч», «Илдар» (Н.Җиһанов) һ.б. операларда биюләр куя. ТАССРның Дәүләт җыр һәм бию ансамблендә 36 хореографик композицияне сәхнәләштерә: «Кияү каршылау», «Өч кыз», «Колхоз яшьләре биюе», «Көтүче һәм сыер савучы», «Батраклар», «Башмаклар», «Зәңгәр шәл», «Мәдрәсәдә булган хәл» һ.б. Т. И.А.Моисеев җитәкчелегендә СССРның Дәүләт акад. бию ансамбле (1949), Әзәрбайҗан дәүләт җыр һәм бию ансамбле (1969), Чуаш АССРның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле (1956, 1982) өчен татар биюләре куя; һәвәскәрләрнең хореография сәхнәсе өчен күп эшли. Төрле сәхнә мәйданчыкларында Т. тарафыннан барлыгы 365 хореографик композиция дөнья күрә, аларга фольклор чыганакларына якынлык, милли характерның сәхнә биеклегеннән чынбарлыкка туры килгән гәүдәләнеше хас, алар ш.у. хореографик текстның һәм лексиканың гадилеге, купшылыгы һәм төгәллеге б-н аерылып тора; бу постановкаларның күбесе татар милли бию культурасының классик үрнәкләре юнәлешендә була.

Х е з м.: Татарские танцы. К., 1984; 100 татарских фольклорных танцев. К., 1986.


*Әд.:* С э й ф у л л и н Р. Ул хәтта «Шүрәле»не дә биетте!.. // Халыкка багышланган тормыш. К., 2012; Г о р ш к о в В.Н. Балетмейстер Гай Тагиров. К., 1997.

**ТАҺИ́РОВ** Индус Ризакъ улы (24.5.1936, Шөгер р-ны Иске Шөгер а.), тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, тарих фән д-ры (1979), ТР ФА академигы (1995), ТАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1986, 1997). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1963), шунда ук эшли, 1980–95 елларда тарих ф-ты деканы, бер үк вакытта, 1983 тән, СССРның совет дәвере тарихы (1992 дән — хәзерге заман Ватан тарихы, 2009–2013 тә — Ватан тарихы) каф. мөдире. Хезмәтләре Россиядә революцион һәм милли азатлык хәрәкәтләре тарихы, Татарстанда милли дәүләт төзелеше мәсьәләренә багышлана. Үзенең фәнни хезмәтләрендә илдә беренчеләрдән булып милли факторның Россиянең иҗтимагый-сәяси үсешенә йогынтысын өйрәнә, борынгы заманнардан алып бүгенге көннәргә кадәр татар халкының милли дәүләтчелек тарихын киң яктырта. Аның тарафыннан «Октябрь революциясендә солдат массалары» («Солдатские массы в Октябрьской революции»), «Милли-демократик оешмалар тарихы» («История национально-демократических организаций»), «Тарихи процессның күп вариантлылыгы мәсьәләсе» («Вопрос о многовариантности исторического процесса»), «Хакимият һәм 1917 елда Россиядә милли мәсьәләне хәл итү алымнарының үзара нисбәте диалектикасы» («Диалектика соотношения характера власти и способов решения национального вопроса в России в 1917 году») кебек зур тарихи темалар эшләнә. «Октябрь Казанда» («Октябрь в Казани», 1967), «Идел буенда һәм Уралда революцион көрәш һәм милли азатлык хәрәкәте (1917 елның февраль–июле)» («Революционная борьба и национально-освободительное движение в Поволжье и на Урале (февраль–июль 1917)», 1977) монографияләрендә Россиядә милли кризисның катлаулы мәсьәләләре һәм 1917 дә аны хәл итү юллары ачыла. Т.ның фәнни эзләнүләре нәтиҗәсендә Г.Баруди, Г.Исхакый, М.Солтангалиев, Ю.Вәлидов, И.Алкин һ.б. зур җәмәгать һәм сәясәт эшлеклеләре исемнәре аклана һәм тарихка кире кайтарыла.

1990 елларда Т. Татарстандагы иҗтимагый-сәяси процессларда, респ-каның суверенлыгын урнаштыруда зур роль уйный, татар милли хәрәкәтенең танылган идеологларыннан берсе була. 1990 да Татарстан тарихында яңа этап башлап җибәргән ТССРның дәүләт суверенитеты турындагы Декларация проектын әзерләүдә катнаша; 1991 дә респ-ка статусы турында Татарстан вәкилләре һәм ил җитәкчеләре арасындагы сөйләшүләр вакытында делегация җитәкчесе урынбасары



Г.Х.Таһиров.



И.Р.Таһиров.

вазифаларын башкара; 1992 дә ТРның яңа Конституциясенең төп нигезләмәләрен эшләүдә катнаша; 1994 нең февраль аенда РФ һәм ТР җитәкчеләре кул куйган «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Шартнамәне әзерләү буенча ТР делегациясе составына керә. ТР ФА Президиумы әгъзасы (2002–07). 1995–2009 да ТР Дәүләт Советы депутаты. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-тын оештыручыларның берсе һәм беренче рәисе (1992–2002). Т. татар халкының милли һәм мәдәни яңарышына, Татарстанның РФ һәм чит ил татар диаспоралары б-н мәдәни һәм икътисади элемтәләрен ныгытуга, татар халкы күпләп яшәгән урыннарда милли-мәдәни автономияләр оештыруга зур өлеш кертә. «Татарстан һәм татар халкы тарихыннан очерклар (XX йөз)» («Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век)», 1999) монографиясе өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2001). Дуслык, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Без тарихта эзлебез. К., 2016; Дорогой свободы и братства. К., 1987; История национальной государственности татарского народа и Татарстана. К., 2000; На изломе истории. К., 2004; История государственности Татарстана. XX век. К., 2005.

*Әд.:* Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Биобиблиогр. словарь. К., 1999; Академия наук Республики Татарстан: Справ. К., 2002; В а л е е в Р. Учёный, политик, человек // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2006. № 1. *Г.С.Сабирҗанов.*

**ТАҺИ́РОВ** Ленар Рәфгать улы (8.5.1954, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1997), проф. (1999). ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2011). 1976 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: теоретик физика кафедрасында (1979 дан), каты җисем физикасы каф. каршындагы фәнни-тикшеренү лаб-ясе җитәкчесе (2004 тән), каты җисем физикасы каф. мөдире (2008 дән). Хезмәтләре утә уткәргечләрдә ЭПР теориясенә карый. Т. локальләшкән моментларның спин релаксациясе һәм уткәрүчәнлек электроннары тизлекләре өчен аналитик аңлатмалар таба. Спектраль сызыклары бериш киңәймәгән утә уткәргечләрдә ЭПР мәсьәләләрен; утә уткәргечләрдә ЭПР сызыкларында диполь киңлекнең алмаш тараюы мәсьәләләрен чишә. Өч үлчәнешле утә уткәргечтә турыдан-туры булмаган Рудерман-Киттель алмашуы гамильтонианын исәпли. Магнит резонансы

алымнары ярдәмендә үтә үткәргечләрнең наноүлчәнешле үзлекләренең табигате өлкәсендәге тикшеренүләр циклы өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2007). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Пространственная дисперсия спиновой восприимчивости электронов проводимости в сверхпроводниках // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1979. Т. 76, вып. 2 (автордаш); Сужение линий ЭПР обменным полем в сверхпроводнике // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1985. Т. 89, вып. 4 (автордаш); Особенности ядерной релаксации в сверхпроводнике с сильными межэлектронными корреляциями // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1989. Т. 49, вып. 8 (автордаш); Magnetic Nanostructures // Springer Series in Materials Science. 2007. V. 94 (автордаш).

**ТАҺИ́РОВ** Марсель Шәрифҗан улы (25.10.1964, Арча р-ны Әйшияз а.), галим агроном, а.х. фән. д-ры (2011), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (2010). ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2013), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2015). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1988), Арча р-ның «Игенче» к-зында агроном булып эшли. 1990–91 елларда ВЛКСМның Арча район ком-тының 2 нче, Әтнә район ком-тының 1 нче секретаре. 1991 елдан «Тукай» совхоз-техникумында директор урынбасары, 1993 тән «Татагрохимсервис» Траст компаниясе» АҖ директоры, 1998 дән Әтнә р-ны хакимияте башлыгының 1 нче урынбасары — А.х. һәм азык-төлек идарәсе башлыгы. 2000 нән Татарстан А.х. фәнни-тикшеренү ин-тында (бүленеп), ген. директор урынбасары, директор (2006 дан). 2003–04 тә «Био-Виктория» күпьеллык үләннәр» ҖЧҖдә ген. директор (Казан). 2004–06 да ТР а.х. һәм азык-төлек министры урынбасары. Хезмәтләре Урта Идел буе шартларында бәрәңгенең югары продуктлы агрофитоценозлары формалашу нигезләрен эшләү мәсьәләләренә карый. Спортның милли төрләре буенча РФнең атказ. спорт остасы (1985), милли көрәш буенча ТРның атказ. спорт остасы (1996).

Х е з м.: Выращивание картофеля на приусадебном участке: Рекомендации. К., 2009; Оздоровлённый семенной картофель. К., 2009 (автордаш); Оптимизация минерального питания картофеля на серых лесных почвах Поволжья // Нива Татарстана. 2009. № 1.

*Әд.:* И л д а р х а н о в И.Г. Без көрәшче халык. К., 2004.

**ТАҺИ́РОВ** Морат Салих улы (5.1.1952, Чистай ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1993), проф. (1995), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2006). 1974 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: магнит радиоспектроскопиясе һәм квант электроникасы лаб-ясендә, гомуми физика каф. профессоры (1993 тән), квант электроникасы һәм радиоспектроскопия каф. мөдире (1999 дан). ТР ФАнең Перспектив тикшеренүләр ин-ты директоры (2015 тән). Хезмәтләре конденсацияләнгән халәт физикасына карый. Т. Ван-Флек парамагнетикларын һәм чикләнгән геометриядә гелий-3 ТМРын тикшергәндә яңа физик эффектлар таба. «Магнит резонансы һәм аның кулланылышының актуаль проблемалары» дип исемләнгән Бөтенроссия яшьләр фәнни мәктәбе җитәкчесе (1997 дән). Ван-Флек парамагнетиклары физикасына караган хезмәтләре өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2006).

Х е з м.: Обнаружение прямой магнитной связи ядер жидкого $^{3}$He с ядрами $^{169}$Tm в кристалле этилсульфата тулия // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1984. Т. 39, вып. 10 (автордаш); О возможности динамической поляризации ядер с использованием ван-флековских парамагнетиков // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1995. Т. 61, вып. 8 (автордаш); Anisotropic magnetization of the Van Vleck paramagnet $LiTmF_4$ at low temperatures and high magnetic fields // J. Phys.: Condens. Matter. 2008. V. 20 (автордаш).

**ТАҺИ́РОВ** Мөхәммәт Хәмзә улы (1895, Казан губ., Казан өязе Мәрҗән а. — 1929), сәясәт эшлеклесе. 1916 елда Россия армиясенә чакырыла, Оренбург шәһәрендә 105 нче пехота запас полкында рота писаре булып хезмәт итә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Оренбург мөселман хәрби ком-тын, Мөселман хәрби-революцион ком-тын оештыручыларның берсе һәм аның рәисе. 1918–19 да Оренбург губерна башкарма ком-тының Мөселман эшләре буенча комис-ты рәисе урынбасары; Бөтенроссия ҮБК каршындагы Төркестан АССР вәкиллегендә «Төркестан» г-тасы мөхәррире; Көнчыгыш фронтның 1 нче армиясе сәяси бүлеге хезмәткәре. 1919–21 дә Башкортстан хәрби комис-ты сәяси идарәсенең оештыру бүлеге башлыгы, РКП(б)ның Башкортстан өлкә ком-ты агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире. 1921–24 тә Мәскәүдә: РКП(б) ҮКның агитация һәм пропаганда бүлеге инструкторы, РСФСР Баш сәяси-агарту ком-тының милли азчылык бүлеге мөдире урынбасары. 1924–28 дә ТАССРның Мәгариф халык комис-тында: халык комиссары урынбасары, халык комиссары, академүзәк рәисе. 1929 да Укытучылар белемен күтәрү ин-тында татар бүлеге мөдире (Казан).

Х е з м.: Октябрь революциясе татарларга нәрсә бирде. К., 1928. *И.Г.Гыйззәтуллин.*

**ТАҺИ́РОВ** Рафаил Барый улы (25.4.1933, Казан — 8.1.2005, Казан), философ, филос. фән. канд. (1972), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993). Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлый (1960). 1954–58 елларда ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы, соңрак ВЛКСМның Совет райкомы 1 нче секретаре, 1959–62 дә ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре. 1962–74 тә профсоюзларның Татарстан советында культура-масса эшләре бүлеге мөдире. 1974–97 дә Мәскәү энергетика ун-ты Казан ф-лында каф. мөдире, 1993 тән иҗтимагый фәннәр каф. профессоры. 1997–2003 тә Казан соц.-юридик ин-тының тарих һәм политология каф. мөдире. Хезмәтләре дин белеменә, политологиягә, этносоциологиягә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Проблемы национального и религиозного современного федерализма // Федерализм: глобальные и российские измерения: Материалы междунар. науч.-практ. конф. К., 1993; Этническое самосознание через призму социологии // Науч. Татарстан. 1995. № 4; Лекции по курсу политологии. К., 2000.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**ТАҺИ́РОВ** Рафаэль Касыйм улы (12.2.1931, Апас р-ны Кормаш а.), авиация двигательләре төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1986). 1955 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1955 тән Үзәк авиация моторлары төзү ин-тында эшли (Мәскәү). Хезмәтләре реактив двигатель һәм очкыч аппарат элементларындагы катлаулы аэрогазодинамик агымнарны матем. модельләштерүгә һәм аларны исәпләү алымнарына карый. Т. тавыш тизлегеннән югарырак тизлекле өзекле һәм өч үлчәнешле агымнар теориясен һәм аларны исәпләү алымнарын эшли; көч җайланмасы б-н очкыч аппарат интеграциясе мәсьәләсен хәл итә. Самолётның койрык өлешендә трансавыш тизлекле ягалап агу күренешен һәм реактив-һава двигателе б-н эшли торган көч җайланмасын матем. модельләштерүгә караган хезмәтләр циклы өчен СССР МСның проф. Н.Е.Жуковский исем. бүләгенә лаек була (1980).

**ТАҺИ́РОВ** Рәфгать Бикмулла улы (17.3.1924, Зөя кантоны Татар Әҗиле а. — 25.4.2015, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1993), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994). 1941–42 елларда Норлат р-ның Күгеш мәктәбендә укыта. 1953 тә Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли (1956 дан), физика ф-ты деканы урынбасары (1957–61), гомуми физика каф. мөдире (1967–85), 1993 тән шул кафедраның профессоры. Хезмәтләре оптик нурланышның матдә б-н үзара тәэсирен тикшерүгә карый. Т. кислородта углерод окисе янганда су молекулаларының актив катнашуын ачыклый, фотодесорбция процессының механизмын өйрәнә. Пыяла өслегеннән су молекулаларының нәсызыкча диссоциатив шартлаулы десорбциясе, адсорблашкан молекулалар фотодесорбциясе вакытында фотокаталитик эффект күренешләрен һәм каты җисем өслегендә үзенчәлекле үзлекләре булган өслекчә кучеш катламы барлыгын ача. Бөек Ватан сугышында катнаша (1942–45). 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Введение в физику высокого вакуума и его применение. К., 1966; Фотофизические процессы при фотодесорбции адсорбитированных молекул воды с поверхности стекла // Хим. физика. 1986. Т. 5, № 6; Об изотермах реальных газов // Изв. вузов. Физика. 1998. № 4 (автордаш).

**ТАҺИ́РОВ** Рәфыйк Рөстәм улы (9.5.1966, Кукмара р-ны Түбән Арбаш а.), драма актёры, ТРның халык артисты (2012). Казан те-



Р.Р.Таһиров Гакыйф ролендә («Утрау», З.Хәким; Нурдидә ролендә Р.Фәйзуллина).

атр уч-щесен (1985), Казан ун-тын (1994) тәмамлый. 1987 елдан Әлмәт татар драма театрында. Күп кенәзур рольләр башкара: Хәйретдин («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), Акъегет («Ай тотылган төндә», М.Кәрим), Зөлкарнәй («Ялкынлы яшьлек», И.Абдуллин); геройларының холыкларын тирәнтен ача белә. Т. башкарган Сираҗетдин («Банкрот», Г.Камал) образы үзенчәлекле булуы б-н истә кала. Аның башкаруында Гофран («Көзнең соңгы яфраклары», Р.Хәмид), рәссам Кәрим («Сагынырсың әле син дә бер», Г.Каюмов), Сөләйман («Сәер кеше», Д.Салихов), Гакыйф («Утрау», З.Хәким) рольләре камил проф. осталык, психол. рәсемнең күппланлылыгы б-н аерылып тора. Т. тудырган Ансар («Туган-тумача», И.Зәйниев), Илфат («Монда тудык, монда үстек», Т.Миңнуллин) образлары тамашачының мәхәббәтен яулый. ТР Мәдәният министрлыгы һәм «Җыен» фондының Д.Сиражиев исем. бүләге лауреаты (1992).




Р.Р. Таһиров.

**ТАҺИ́РОВ** Рәфыйк Хәниф улы (4.4.1941, Мәскәү — 23.2.2004, шунда ук), спортчы, тренер (ирекле көрәш, грек-рим көрәше), СССРның спорт остасы (1962), СССРның атказ. тренеры (1989), Бөтенсоюз категорияле судья (1975). Үзәк физик культура ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1967). Спорт б-н 1955 елда Сов. Армиясенең Үзәк йортында шөгыльләнә башлый (тренер — П.С.Евдокимов). 1964–74 елларда Мәскәү шәһәр советы «Локомотив» ирекле спорт җәмгыятенең өлкән тренеры, 1974–78 дә Бөтенсоюз физик культура фәнни-тикшеренү ин-тында өлкән фәнни хезмәткәр, 1979–85 тә Профсоюзларның спорт җәмгыяте идарәсе башлыгы, 1985–90 да СССР җыелма командасы тренеры (грек-рим көрәше буенча РСФСР җыелма командасы өлкән тренеры), 1992–99 да РФ Президенты каршындагы Алтай Респ-касы вәкиллегенең ярдәмче-консультанты.


**ТАҺИ́РОВ** Рем Касыйм улы (2.4.1933, Казан — 7.12.1996, Удмурт Респ-касы, Ижевск ш.), график-рәссам, Удмурт АССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991). Казан сәнгать уч-щесен (1954), В.И.Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тын тәмамлый (1960, проф. Е.А.Кибрик остаханәсе). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1962). Удмурт графика мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Удмурт пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тын ачуга өлеш кертә, шунда укыта (1960–95), 1991 дән — доцент. «Карадиңгезчеләр» — Т.ның ин-тта уку елларында эшли башлап, 1969 га кадәр дәвам иткән аеруча билгеле төсле литографияләр сериясе. Алар «Огонёк», «Юность», «Молодая гвардия» ж-ларында, сәнгать энциклопедияләрендә, ш.у. аерым эстамплар һәм открыткалар җыелмасы рәвешендә репродукцияләнә. Гравюраларның сюжетларын хәрби өйрәнүләр һәм диңгезчеләр тормышы тәшкил итә. Сериянең төрле рухтагы һәм төрле темага караган әсәрләре батырлык һәм түземлек таләп иткән Кара диңгез диңгезчеләре тормышының бердәм картинасын тудыра. Моны төсләр чишелешенең тыенкылыгы да ассызыклый. Рәссам диңгез киңлекләренең чиксезлеген күрсәтү өчен горизонталь җәелдерелгән композиция куллана, бер форматтагы битләрдән файдалана. Сериянең соңгы картиналарында Т. аклы-каралы сурәтләүгә күчә: «Флаг күтәрү», «Тревога», «Көндезге аш», «Палуба юу», «Очрашу», «Диңгез манёврлары» (1967–69). График әсәрләрдән тыш гуашь һәм майлы буяулар б-н башкарылган картиналары да бар: «Кыска ялда», «Яхт-клуб», «Бухтага керү». Алар гади сюжетларга, буяу төсләренең ачыклыгына һәм таплар бәйләнешенә корылган, һәркайсыннан үтә күренмәлелек, яктылык, җиңеллек бөркелә, Удмуртия тарихына мөрәҗәгать итеп, ул Мултан эше б-н бәйле картиналар сериясен иҗат итә. Рәссам 1980 еллар ахырында — 1990 еллар башында акварель техникасында рус язучыларының әсәрләренә иллюстрацияләр ясый. Акварель картиналарының темасы — портретлар, пейзажлар, натюрмортлар, ялангач сурәтләр. Алга таба Т. яңа материаллар һәм техник алымнар үзләштерә. Шуның нәтиҗәсе буларак, Ижевскидагы Мәңгелек ут янында Сугышчан һәм хезмәт даны монументы өчен металлга чүкеп бизәк төшерә (1978, скульп. Б.К.Волков, архитекторлар Г.С.Пономарёв, А.Г.Мифтахов). Удмуртиядә ел саен мәктәп укучылары арасында академик рәсем буенча Таһиров исем. респ-ка конкурсы уздырыла.

**ТАҺИ́РОВ** Рифгать Шакиржан улы (17.10.1903, Казан — 2.7.1977, шунда ук), тарихчы, төбәкне өйрәнүче, педагог, тарих фән. канд. (1949). Ш.Ә.*Таһировның* улы. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1928). 1919 елда аяк киемнәре ф-касында эшли, аннан соң Екатеринбург шәһәрендәге Үзәк мөселман китапханәсендә китапханәче өйрәнчеге. 1920–22 дә Урал ун-ты эшчеләр ф-тында тыңлаучы (Екатеринбург). 1922 дә Таһировлар гаиләсе Казанга кайта. 1922–23 тә Казан ун-ты эшчеләр ф-тында укый. 1925 тән ТАССР Мәгариф халык комис-ты коллегиясе секретаре. 1928–29 да Казанда М.Вахитов исем. 2 нче мәктәптә җәмгыять белеме укыта; 1928–30 да *Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыятендә* гыйльми секретарь. 1930–42, 1945–77 дә Казан пед. ин-тында: укытучы, декан ярдәмчесе, тарих ф-ты деканы (1947 дән), проф. (1976 дан). Бер үк вакытта, 1948 дән, Казан ун-тында тарих укытучысы, 1950 дән ВКП(б) ҮК каршындагы Югары партия мәктәбе читтән торып уку бүлегенең Казандагы консультация пунктында гомуми тарих укытучысы. Бөек Ватан сугышында катнаша.

Эшчеләр ф-тында һәм Казан пед. ин-тында укыган елларда Т. ТАССР, Мари һәм Чуваш автономияле өлкәләре терр-яләрендә археол. экспедицияләрдә катнаша. РСФСР китапханәчеләренең 1 нче съезды (Мәскәү, 1924), 1 нче Бөтенсоюз тюркологлар съезды (Баку, 1926) делегаты. ТАССРда Китап палатасын булдыруны башлап йөрүчеләрнең берсе (к. *Татарстан Республикасы китап палатасы*); «ТАССР китап палатасы турында нигезләмә»не эшләүдә катнаша (1926). Мәскәү ун-ты каршындагы Рус библиографлар җәмгыяте әгъзасы (1927). Татарстан һәм татар халкы тарихын өйрәнү б-н шөгыльләнүче төрле фәнни һәм җәмәгать-төбәкне өйрәнү оешмаларында актив катнашучы буларак, «Татарстан» энциклопедия сүзлеген (11 томда) булдыру фикерен алга сөрә. 1972 дә шундый хезмәт нәшер итү тәкъдиме б-н ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тына хат б-н мөрәҗәгать итә. Мәсьәлә хәл ителмичә кала, әмма Т. әлеге хезмәт өчен материаллар — күренекле эшлеклеләр, үткән һәм хәзерге заман тарихындагы танылган шәхесләр турында биографик мәгълүматлар туплау эшен дәвам итә; бер үк вакытта «Татарстан тарихчылары. 1917–1977 еллар» («Историки Татарстана». 1917–1977 гг.») биобиблиографик сүзлеген эшли (1977 гә китап, нигездә, язылып бетә, әмма Т. аны бастырырга өлгерми). Сугыштан соңгы еллардагы фәнни эзләнүләре 1 нче Интернационал һәм аның каршындагы Рус секциясе тарихы һәм историографиясе, Ватан тарихы, төбәк тарихы, тарих укыту методикасы, библиография һәм китапханәләр эше мәсьәләләренә багышлана. Т. беренчеләрдән булып Г.Ибраһимов, Г.Коләхмәтов, Г.Сәйфетдинов һ.б. күренекле татар галимнәренең, язучыларының һәм сәясәт эшлеклеләренең тормышын һәм иҗатын өйрәнә башлый. Укытучылар өчен «Иң яңа тарих» («Новейшая история», 1958) уку-укыту-методик ярдәмлеге авторларының берсе һәм мөхәррире. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, «РСФСР халык мәгарифе отличнигы» күкрәк билгесе б-н бүләкләнә.



Р.Ш. Таһиров.



Ф.Ш. Таһиров.

Х е з м.: Русская секция Международного товарищества рабочих и Россия // Уч. зап. Казан. гос. пед. ин-та. 1949. Вып. 7; Русская и советская историография Первого Интернационала. К., 1968.

*Әд.:* Научные исследования в Казанском государственном педагогическом институте. К., 1976; Рифгат Шакирзянович Тагиров // Советская библиография. 1977. № 6; К 75-летию со дня рождения Р.Ш.Тагирова // Совет мәктәбе. 1978. № 9; Т ы р и н о в В.В. Краеведческая деятельность Р.Ш.Тагирова // Историческое краеведение в Татарстане: Материалы респ. науч. конф. К., 2004; Учёный, педагог, гражданин: Сб. материалов к 105-летию со дня рождения Р.Ш.Тагирова. К., 2008.

*Г.С.Сабирҗанов, И.Х.Кадыйров.*

**ТАҺИ́РОВ** Фаик Шакиржан улы (16.10.1906, Казан губ., Зөя өязе Олы Ачасыр а. — 28.3.1978, Мәскәү), график, китап рәссамы, техник фән. канд. (1939). Ш.Ә.*Та-*

*һировның* улы. 1920–22 елларда Оренбургтагы Урал татар-башкорт пед. курсларында укый; бер үк вакытта зәркән остаханәсендә эшли, Пролеткультның сынлы сәнгать студиясендә шөгыльләнә. 1922 дән Казан сәнгать-техника ин-тында, 1925 тән Мәскәүдә Бөтенсоюз сәнгать-техника остаханәләренең (ВХУТЕМАС) полиграфия ф-тында күренекле рәссамнар В.А.Фаворский һәм Л.А.Брунида укый. Институтны тәмамлаганнан соң, 1929 да, РСФСР Халык мәгарифе комис-ты тарафыннан сәнгать-полиграфия белеме алу өчен, Германиягә берьеллык командировкага җибәрелә. 1930–34 тә Мәскәүдәге «ГОЗнак» ф-касында эшли һәм Мәскәү полиграфия ин-тының нәшрият ф-тында укыта, «Шрифт теориясе һәм практикасы» дигән яңа курс оештыра. 1934–37 дә Бөтенсоюз яңа алфавит үзәге ком-тының полиграфия, стенография һәм язу машинкасында басу секторы мөдире. 1938–41 дә РСФСР Дәүләт китап-журнал нәшриятлары берләшмәсенең Полиграфия һәм нәшрият техникасы фәнни-тикшеренү ин-тында яңа төзелгән шрифт лаб-ясен җитәкли. 1946 дан полиграфия машиналары төзелеше фәнни-тикшеренү ин-тының яңа шрифтлар бүлеге мөдире, шрифтларның төп нөсхә рәсемнәрен эшләү һәм шрифтлар эшләүнең теоретик мәсьәләләрен хәл итү б-н шөгыльләнә; 1963 тән Азия халыклары шрифтлары секторы б-н җитәкчелек итә. «Сулф» (1923), «ТатЛЕФ» (1923), «Октябрь» (1927–32), «Яшь Октябрь» (1928–32) иҗат берләшмәләре әгъзасы.

Т. — 1920–30 елларда конструктивистик юнәлештә иҗат итүче әйдәп баручы совет графикларының берсе, илебездә шрифт эшенең күренекле оештыручысы — татар китабын заманча сәнгатьле бизәүнең 1920 елларда гарәп каллиграфиясе һәм Европа сәнгатенең авангард ысуллары традицияләре кушылмасын тәшкил иткән нигезләрен сала.


Т.ның актив иҗат эшчәнлеге 1924 тә Татгосиздат өчен китаплар бизәүдән башлана. 1927 дә «Яңалиф» нәшрияты өчен эшли башлый (татар алфавитын латинлаштыру яклы була, 1928 дә әлеге темага берничә плакат һәм реклама басмалары бизи, сеңлесе С.Ш.*Таһирова* б-н бергә, балаларны яңа татар алфавитына өйрәтү өчен, «Безнең алфавит» дигән буяусыз рәсемле әлифба чыгара); «Нәшрият» һәм СССР халыкларының үзәк нәшриятлары, СССРдагы чит ил эшчеләренең Мәскәүдәге нәшрияты һ.б. б-н хезмәттәшлек итә. 30 дан артык китап, ш.и. — Г.Кутуйның «Көннәр йөгергәндә» (1924), К.Нәҗминең «Өермәләр» (1924), В.Уразайның «Серле шалаш» һәм «Еллар карынында» (икесе дә — 1925), Г.Нигъмәтинең «Әдәбият мәйданында» (1925), Ш.Усмановның «Памирдан радио» (1926), Чыгътайның «Дин корбаннары» (1927), Х.Хәйринең «Хәсән нигә кызылармияче булды» (1927, А.Коробкова б-н берлектә), «Чабата» (1928), Ф.В.Гладковның «Цемент» (1928) китапларын бизи. 1920 еллар уртасында Т.ның китап бизәүдәге яңалыгы куфи ысулында стильләштерелгән язуларны фотомонтаж һәм ачык төсләрдәге өстәмә элементлар б-н берләштергән яңа типтагы рәсемле китап тышлыклары эшләүдә чагыла. 1920 еллар азагында аның арсеналында җыелма бизәү алымнары (акциденция һ.б.) торган саен күбрәк урын яулый бара. К.Эдшмидның рәссам тарафыннан тәҗрибә рәвешендә бизәлгән «Басклар, үгезләр, гарәпләр» (1929) һәм «Нью-Йорк» (1933) китаплары совет китап бизәү сәнгате тарихына кереп кала.

Т. 1920 еллар татар вакытлы басмаларын сәнгатьчә бизәүгә лаеклы өлеш кертә. Ул «Игенчеләр», «Эшче» үзәк татар г-талары, «Кечкенә иптәшләр» ж-лы б-н хезмәттәшлек итә, мәкалә исемнәре һәм рубрикалар өчен шрифтларның яңа рәсемнәрен әзерли, еш кына фотомонтаж куллана. Т. совет графика дизайнының беренче пионерларыннан була. 1925 нең 1 Маена Казандагы Театр мәйданын (хәзер Ирек мәйданы), Окт. рев-циясенең 10 еллыгына (1927) Мәскәүдәге тантаналы митинглар өчен бер типтагы трибуналар бизәүдә һ.б.да катнаша.

1930 еллар уртасыннан, китап бизәүдәге конструктивистик алымнар неоакад. ысуллар б-н алмашынгач, Т. китап дизайныннан баш тарта һәм шрифтлар әзерләү б-н шөгыльләнә. Рус, латин, әрмән, грузин, корея, һинди, пәнҗаби һ.б. алфавитлар нигезендә басма өчен җыелма шрифт рәсемнәре эшләү системасын төзи. Язу теориясе, типографик шрифтларны стандартлаштыру буенча хезмәтләр һ.б. авторы. Сугышка кадәр Т. лаб-ясендә «әдәби», «академик» һәм «гади яңа гарнитура» әзерләнә һәм машина б-н җыюга күчерелә. Сугыштан соң Т. җитәкчелегендә үзәк газеталар («Правда», «Известия», «Труд»), журналлар һәм матур әдәбият җыю өчен «балтика», «банников», «Лазурский», «журнал гарнитурасы» һ.б. гарнитуралар әзерләнә (әлеге гарнитуралар хәзерге көндә дә кулланыла). Т. эшләгән төп шрифтлар: «гурмукхи-халык гарнитурасы» (пәнҗаби), «Таһиров-бхилаисы» (һинди), «Таһиров квадратлысы», «Таһиров акцидентлысы», «Илья Муромец» (рус). ЛЕФның лаб.-җитештерү хезмәтләреннән төзелгән 2 нче сынлы сәнгать күргәзмәсендә (1925); СССР халыкларының юбилей күргәзмәсе (1927, Казан), «Октябрь» берләшмәсенең 1 нче күргәзмәсе, яшь рәссамнар күргәзмәсе (икесе дә — 1930), 2 нче шрифтлар һәм орнаментлар күргәзмәсендә (1961) (барысы да — Мәскәү); халыкара — бизәлеш сәнгате (Париж, Франция, 1925); «Бишьеллык фронтында» («Октябрь» берләшмәсе) (Берлин һәм Германиянең башка шәһәрләре, 1930), «Китап сәнгате» (Париж, Лион, Франция, 1931–32), совет графикасы (Чикаго, Сан-Франциско һәм Нью-Йорк шәһәрләре, АКШ, 1932–33), 4 нче халыкара китап (Лейпциг ш., Германия, 1959), «ИНПОЛИГРАФМАШ-69» (Мәскәү) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1979 да һәм 2006 да уздырыла (Казан). Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда саклана.

Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Ф.Ш.Таһиров. Китап тышлыклары эскизлары.
1. «Театрдан клубка». Кәгазь. Гуашь. 1927. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее;
2. «Еллар карнында». Вил Уразай. Кәгазь. Тушь. Фотомонтаж. 1925.

Х е з м.: Удобочитаемость графем новых латинизированных алфавитов. М., 1937; Некоторые вопросы построения рисунков шрифтов // Сб. тр. науч.-исслед. ин-та полигр. машиностроения. 1959. № 5; «Остромирово Евангелие» и создание нового шрифта // Искусство книги. М., 1961. Вып. 2. О развитии шрифтового дела в Советском Союзе // Книга: Исследования и материалы. 1966. Сб. 13; Новые проекты стандартов на типографические шрифты // Полиграфия. 1971. № 8; Многонациональная шрифтовая культура // Полиграфия. 1972. № 12.

*Әд.:* Д у л ь с к и й П.М. Оформление татарской книги за революционный период. К., 1930; Р о в е н с к и й М. Учёный, организатор, художник // Полиграфия. 1991. № 7; К о р о б к о в а А.Н. Автобиография и некоторые воспоминания о художественных школах 20-х годов Казани и Москвы // Советское искусство 20–30-х годов. К., 1992; Пионеры конструктивизма: Фаик Тагиров, Александра Коробкова в Казани и Москве: Каталог выставки. К., 2006; У л е м н о в а О.Л. Художественные миры рода Тагировых // Казань. 2008. № 4.

*О.Л.Улемнова, Р.Г.Шаһиева.*

**ТАҺИ́РОВ** Фоат Гайфулла улы (31.3.1917, Казан губ., Зөя өязе Шушырмә а. — 28.11.1996, Казан), актёр, курчак театры режиссёры, ТАССРның халык артисты (1975). Казан курчак театрына нигез салучылардан берсе. Татар акад. театры каршындагы студияне тәмамлаганнан соң (1934), Казан курчак театрында эшли башлый; кулга киеп уйнала торган курчак уены техникасын уңышлы үзләштерә, Петрушка ролен башкара. Бөек Ватан сугышында катнаша. Яралангannан соң (1942), курчак театрына әйләнеп кайта, аның сәхнәсендә немец генералы фон Краузе («Кечкенә партизаннар», Ш.Зәйни), Гитлер («Нәфрәт чәчәкләре», С.Преображенский) образларын гәүдәләндерә. Т.ның

Балда, кенәз Гвидон (А.С.Пушкин әкиятләре буенча), Тархан, Әбүгалисина («Хуҗа Насретдин», шул исем. әсәр буенча, Н.Исәнбәт), Камыр батыр, Дутан батыр (шул исем. әсәрләр буенча, С.Хөсни) рольләрен уңышлы башкаруы, курчак уйнату техникасы б-н виртуозларча эш итә белүе һәм истә калырлык, тәэсирле характерлар тудыра алуы аңа театрның әйдәп баручы осталары рәтенә чыгарга мөмкинлек бирә. Күп кенә курчак спектакльләренең сценарийларын (ш.и. «Кәҗә белән Сарык», Г.Тукай әкияте буенча) эшләүдә катнаша, аларны татарчага тәрҗемә итү б-н шөгыльләнә. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Игламов Р.М. Искусство играющих кукол. К., 2004. *Д.Ә.Гыймранова.*

**ТАҺИ́РОВ (ТАҺИРИ́)** Шакирҗан Әхмәтҗан улы (28.2.1858, Казан губ., Зөя өязе Олы Ачасыр а. — 14.1.1918, Казан), педагог, хаттат, рәссам, статский советник (1915). Ахун гаиләсендә туган. Башлангыч белемне туган авылы мәктәбендә ала. «Мәрҗания» мәдрәсәсендә (Казан) укый, Оренбург Мөселман Диния нәзарәтендә имам-хатип һәм мөдәррис дәрәҗәсенә имтихан тапшыра (1877). 1880 елда Казан татар укытучылар мәктәбен (КТУМ) тәмамлый. Уку елларында Г.Ю.*Филиппус*, Х.Г.*Пашковскийдан* рәсем һәм нәкышь дәресләре ала. 1883 тә Т., татарлардан беренче булып, С.-Петербург САннән башлангыч мәктәпләрдә рәсем дәресе укытырга хокук бирүче таныклык ала. 1880 нән — рус-татар уч-щеләрендә һәм Казан мәдрәсәләре каршындагы рус классларында, бер үк вакытта, 1881–1917 дә, КТУМда сызым һәм рәсем дәресләре укыта. 1896–1917 дә Казан мәдрәсәләрендә — рус теле, 1907–17 дә Казан коммерция уч-щесендә — гакыйдә, каллиграфия, рәсем һәм сызым, Казан 1 нче реаль уч-щесендә гакыйдә дәресләре бирә. Февраль рев-циясеннән соң (1917) Казанда һәм Чистайда укытучылар курсларын оештыру б-н шөгыльләнә. Т. татар мәгарифе үсешенә сизелерлек өлеш кертә, төп игътибарны туган телне үстерүгә һәм сынлы сәнгатькә тискәре мөнәсәбәтне бетерүгә юнәлтә. Шәхси акчасына рус-татар уч-щесе бинасы төзи, *Ләбибә Хөсәения мәктәбен* оештыруда катнаша. К.Д.Ушинскийның пед. ысуллары юлыннан бара, рус телен өйрәнү өчен беренче методик кулланмалар әзерли. Рус һәм чит телләрне уңышлы үзләштерү өчен укучыларга туган тел грамматикасын белү кирәк дип саный, шуның б-н татарларны ассимиляцияләүгә юнәлдерелгән рәсми империя сәясәтенә объектив каршы тора.



Мөхәммәд әл-Бусириның «Мөхәммәднең бөркәнчегенә мәдхия» кулъязма китабының унваны (титул бите) һәм китап бите. Кәгазь. Тушь. Акварель, алтын. 1883. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Аваз ысулы б-н өйрәнү өчен беренче рәсемле татар әлифбаларыннан «Бәдьэ әт-тәгълим һәм мөкәммәл әлифба» («Башлангыч белем бирү һәм тулы гарәп әлифбасы», 1893; 6 басма, Тулы гарәп әлифбасы, 1916) китабы, аңа методик ярдәмлек (1893), гарәп теле дәреслеге (1905); дөньяви уку йортлары өчен мөселман дине тәгълиматы буенча уку ярдәмлекләре: «Абдәст вә намаз рисаләсе» («Тәһарәт һәм намаз турында китап», 1893; 3 басма, 1913), «Мохтасар кавагыйд-әт-тәҗвид» («Тәҗвиднең кыскача кагыйдәләре», 1899; 2 басма, 1915), «Тарихе ислам замане хөләфа» («Хәлифәләр заманнарындагы ислам тарихы», 1914) авторы. Т.ның укучылары арасында күренекле шәхесләребездән Г.Исхакый, Г.Коләхмәтов, М.Корбангалиев, М.Солтангалиев, М.Фазлуллин, Х.Ямашев һ.б. бар. Урта гасыр гарәп шагыйре Мөхәммәд әл-Бусириның «Мөхәммәднең бөркәнчегенә мәдхия» әсәрен кулъязма китап итеп эшләве (1883) Т.ның рәссамлык талантына ия булуы турында сөйли. Анда Т. гарәп язуының *нәсх*, *тәгъльйкъ* кебек стильләрендә оста эш итүен күрсәтә. Китап бизәүдә төсләр куллана, битне ике сызык б-н каймалап һәм төп текстны юлга-юл тәрҗемәдән аерып, кәгазь бите яссылыгы төзи, кырларга аңлатмалар чыгара һәм, текст композициясенә динамика өстәп, аларны диагональ буенча урнаштыра. Фронтиспис (сәрләүхә) үсемлек орнаменты б-н бизәлә, унван һәм бисмилләһнең аркасыман композициясе чәчәк гирляндасы б-н каймаланган. Зәңгәрле-яшелле төп төсләр гаммасына ачык кызыл бөрчекләр төшкән. Т. кулъязмадагы кайбер сүзләргә үзенең юлга-юл аңлатмаларын һәм тәрҗемәләрен биргән.

1904 тә матур язу дәресен күпьеллык укыту тәҗрибәсенең нәтиҗәсе булган һәм Казан уку-укыту округындагы рус һәм татар мәктәпләрендә киң кулланылган кисмә рус әлифбасын бастырып чыгара һәм элмә «Туры шрифтлы Генетик рус язуы таблицалары»н нәшер итә. 1914 тә Т.ның каләм һәм тушь б-н эшләнгән 80 нән артык рәсеме урнаштырылган «Рәсемле әлифба» («Фонетик рәсемле татар әлифбасы») китабы басылып чыга. Хайваннар һәм кошлар, шәһәр һәм авыл йорты кирәк-яраклары сурәтләнгән күпсанлы рәсемнәр арасында шул чордагы Казан татарлары тормышын чагылдырган жанрлы күренешләр аерылып тора. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана. Т. 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары, ике «Тырышлык өчен» көмеш медале б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Әхмәров Г. Әлифба китапларына тәнкыйть. К., 1909; Ибраһимов Ф.И. Белем әлифбадан башлана (Татарча грамотага өйрәнү методикасы тарихы һәм әлифбалар). К., 1973; Казанская татарская учительская школа 1876–1917 гг.: Сб. док. и материалов. К., 2005; Шакирджан Тагиров — педагог, просветитель, художник. К., 2008.

*О.Л.Улемнова, В.Р.Таһиров.*



Ф.Г.Таһиров.



Ш.Ә.Таһиров.

**ТАҺИ́РОВ** Энгель Ризакъ улы (4.8.1940, Шөгер р-ны Иске Шөгер а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1989), проф. (1990), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1989), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1967). 1967–70 елларда Казан химия-технол. ин-тында укыта, бер үк вакытта ВЛКСМ ком-ты секретаре. 1972–84 тә Казан авиация ин-тында. 1985–89 да Казан мәдәният ин-ты проректоры. 1989 дан Казан финанс-икътисад ин-тында, тарих һәм политология каф. мөдире. Хезмәтләре татар халкы һәм Татарстан тарихына, дөнья мәдәнияте үсеше, толерантлык, цивилизацияләр мөнәсәбәте, яшьләр сәясәте мәсьәләләренә карый. Т. этноконфессиональ конфликтларны дисциплинара өйрәнү өлкәсендәге мәсьәләләрне өйрәнү б-н шөгыльләнә, югары белем бирүнең сыйфатын камилләштерү һәм күтәрү концепцияләрен эшли. Ватан тарихы, Татарстан тарихы, политология дәреслекләре авторы. ТРның милли конфликтология үзәгенә, ЮНЕСКОның Дөнья мәдәнияте ин-тына нигез салучы, Россия гуманитар фәннәр академиясен оештыручы, аның вице-президенты (1995). БМО, ЮНЕСКО, Европа Советы фәнни программаларын гамәлгә ашыруда катнаша. Халыкара «Европа-Азия» гуманитар академияне оештыручыларның берсе, аның президенты (1989 дан). ТР Иҗтимагый палатасы әгъзасы (2007 дән). «Иң борынгы заманнардан алып хәзерге заманга кадәр дөнья мәдәниятләре контекстында татар халкы тарихы» («История татарского народа в контексте культур мира с древнейших времён до современности», 2010) хезмәтләр циклы өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2010). Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Культура мира — идеология развития человечества. К., 2014; Регионология: Основы региональной политики. К., 2004; Высшая школа: приоритеты модернизации. К., 2006; На перекрёстке цивилизаций: История татар в контексте культуры мира. К., 2007; Народ в пути: История Татарстана в контексте мировой цивилизации. К., 2008.

**ТАҺИ́РОВА** Майя Афзал кызы (8.2.1931, Уфа ш. — 9.6.2003, шунда ук), балет артисты, педагог, РСФСРның атказ. артисты (1955), язучы А.М.*Таһировның* кызы. 1949 елда — Ленинград хореография уч-щесен (педагоглары — Л.М.Тюнтина, Н.А.Камкова, А.Я.Ваганова), 1975 тә Дәүләт театр сәнгате ин-тының театр ф-тын тәмамлый. 1949–71 дә Башкорт опера һәм балет театры солисты. 1972–73 һәм 1978–95 елларда Ф.Ә.Гаскәров исем. Башкорт халык биюе ансамбле педагог-репетиторы. 1995–2003 тә Башкорт хоре-

ография уч-щесендә актёрлык осталыгы педагогы, бер үк вакытта, 1999–2001 дә, уч-щенең сәнгать җитәкчесе. Искиткеч табигый сәләте (югары адым ясау, зур араны җиңел генә сикерү, сәхнәдә образга керә белү осталыгы), классик бию техникасын үзләштерүгә балеринага истә калырлык лирик, драматик һәм комик образлар иҗат итәргә мөмкинлек бирә.

Төп партияләре: Зәйтүнгөл («Торналар җыры», Л.Б.Степанов), Одетта-Одиллия («Аккош күле», П.И.Чайковский), Жизель (шул исем. әсәр буенча, А.Адан), Сари («Яшен сукмагы буйлап», К.А.Караев), Гөлнәзирә (шул исем. әсәр буенча, Н.Г.Сабитов), Галимә («Кара йөзләр»; Х.Ш.Зәимов, А.Г.Чугаев).

Бөтенсоюз балет артистлары конкурсы (1957), Бөтенроссия эстрада артистлары конкурсы (1963), БАССРның Г.Сәләм исем. респ-ка бүләге (1969) лауреаты.

Х е з м.: Уроки башкирского и характерного танца. Уфа, 1982 (автордаш).

*Р.Н.Хәбирова.*

**ТАҺИ́РОВА** Наилә Фәрит кызы (8.7.1960, Куйбышев ш., хәзерге Самара ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1999), проф. (2001). Куйбышев ун-тын тәмамлый (1983). 1979 елдан Куйбышев план ин-тында (хәзер Самара икътисад ун-ты), 2000 нән икътисади тарих каф. мөдире. Хезмәтләре Россиянең, ш.и. 19 йөзнең 2 яртысы — 20 йөз башы Идел буе икътисади тарих мәсьәләләренә, Россиядә базар мөнәсәбәтләре үсеше үзенчәлекләрен өйрәнүгә карый. Т. шәхси җирбиләүчелек формалашу һәм җирдән файдалану, икмәк базары, Идел буе губерналарының икътисади-сәүдә мөнәсәбәтләре, икътисади районлаштыру, базар инфраструктурасы мәсьәләләрен өйрәнә.

Х е з м.: Рынок Поволжья (вторая половина XIX — начало XX вв.). М., 1999; История Самарского Поволжья с древнейших времён до наших дней. Вторая половина XIX — начало XX вв. М., 2000 (автордаш); История Самарского Поволжья с древнейших времён до наших дней. XX век (1918–1998). М., 2000 (автордаш).

*Әд.:* Н о с к о в А.И. Профессора, доктора наук Самарского государственного экономического университета (1931–2009 гг.). Самара, 2009.


**ТАҺИ́РОВА** Суфия Шакирҗан кызы (25.11.1888, Казан — 6.5.1970, шунда ук), библиограф. Ш.Ә.*Таһировның* кызы. 1902 елда шәһәр башлангыч уч-щесен тәмамлый, 1910 да, башлангыч мәктәп укытучысы исемен алу өчен, Казан татар укытучылар мәктәбендә экстерн тәртибендә имтиханнар тапшыра. 1906–18 дә *Хөсәения Ләбибә мәктәбендә* укыта. *Яңалифтәге* рәсемле беренче татар әлифбасы авторларыннан берсе (1928). 1919 дан Казан китапханәләрендә эшли. 1921 дә — М.Вахитов исем. Шәрекъ үзәк китапханәсен, 1923 тә Г.Тукай исем. татар балалар китапханәсен (хәзер Үзәкләштерелгән балалар китапханәләре системасының 24 нче ф-лы) оештыра, 1929 га кадәр алар б-н җитәкчелек итә. 1928–32 елларда ТАССР Китап палатасында библиограф. 1940–50 дә ВКП(б)ның Казан шәһәр ком-ты партия кабинеты китапханәчесе. Татар китабы библиографиясен төзүнең фәнни нигезен эшли.

Х е з м.: Китапханә эше техникасы (Авыл һәм шәһәрләрдәге төбәк китапханәләре өчен куллан-ма). К., 1925; Гыйльми библиография (1925 елда чыккан татарча әсәрләр өчен). К., 1929; Татарстанда чыккан татарча басмаларның гомуми библиографиясе. К., 1930.

*Әд.:* М а х м у т о в а А.Х. Пора и нам зажечь зарю свободы! К., 2006.

**ТАҺИ́РОВЛАР**, фән һәм мәдәният эшлеклеләре династиясе. Нигез салучы — рәссам һәм педагог Ш.Ә.*Таһиров* (1858–1918). Балалары: Зөһрә Салихова (1884–1980), педагог; С.Ш.*Таһирова* (1888–1970), библиограф; Йосыф (Юрий Николаевич) Таһиров (1892–1971), мина-шартлату эше белгече, Югославия Корольлеге армиясе генералы; Әхмәтсолтан Таһиров (1890–1973), төзүче-инженер; Әхмәтзәки Таһиров (1899–1975), тарихчы; Р.Ш.*Таһиров* (1903–77), тарихчы; Ф.Ш.*Таһиров* (1906–78), рәссам. Оныклары: Р.С.*Салихова* (1910–85), педагог; Һ.С.*Салихов* (1913–71), математик; Эрнест Әхмәтзәки улы Таһиров (1937 дә туган), физик; Флёра Әхмәтзәки кызы Таһирова (1942 дә туган), физик; В.Р.*Таһиров* (1952 дә туган), физик. Оныкларының балалары: Леонард Һарун улы Салихов (1939 да туган), математик; Илсөя Һарун кызы Салихова (1943 тә туган), математик; Татьяна Борисовна Таһирова (1961 дә туган), Югославия журналисты, Й.Таһировның оныгы. Оныгының оныгы — Л.Л.*Салихова* (1965 тә туган), педагог һәм математик.

**ТАШ ГАСЫ́Р**, кешелек тарихының хезмәт һәм сугыш кораллары ясау өчен башлыча таш кулланылган иң борынгы дәвере. Т.г.да ш.у. агач, сөяк, тире, каен тузы, үсемлек җепселләре һ.б. киң файдаланыла, аның соңгы чорында, *неолитта*, яңа материал — керамика барлыкка килә. «Т.г.» атамасы фәнгә 1816–19 елларда археолог К.Ю.Томсен тарафыннан кертелә. Татарстан терр-ясендә Т.г. истәлекләрен А.Х.Халиков, М.Г.Косменко, О.Н.Бадер, М.З.Паничкина, З.А.Абрамова, Р.С.Габәшев, М.Ш.Галимова һ.б. өйрәнә, аларның төрләрен һәм чорларын билгели. Т.г.ның хронологик кысалары — фаразланганча, кешенең хайваннар дөньясыннан аерылган вакытыннан (3 млн. еллар чамасы элек) алып металл барлыкка килгән вакытка кадәрге (Борынгы Көнчыгышта 8–9 мең еллар чамасы элек, Европада 6–7 мең еллар чамасы элек, Татарстан терр-ясендә 3–4 мең еллар элек) чор. Борынгы Т.г. — *палеолит* (3 млн. еллар элек — б.э.к. 10 мең ел), урта Т.г. — *мезолит* (б.э.к. 10 мең — 5 мең ел), яңа Т.г. — неолит (б.э.к. 8–3 мең ел) аерып күрсәтелә. Неолитка кадәр кешелек бары тик үзләштерүче тормыш рәвеше (җыючылык, аучылык, балыкчылык һ.б.) алып бара, неолит чорында игенчелек һәм терлекчелек барлыкка килүен чагылдырган беренче мәгълүматлар ачыклана, җитештерүчән хуҗалык формалаша башлый. Т.г. тарихын археол. чорларга бүлү күбесенчә таш индустриядәге үзгәрешләр б-н бәйле: һәр чорга ташны телүнең һәм аны икенчел эшкәртүнең аерым бер алымнары, эшләнмәләрнең үзенчәлекле яки аеруча киң таралган үзенчәлекле формалары хас була. Т.г. борынгы община строеның барлыкка килү, чәчәк ату һәм таркалу чорларына туры килә. Т.г.ны *бронза гасыр* алмаштыра. Алар арасын кыска вакытлы күчеш чоры — *энеолит* били. Аның эзләре һәркайда да очрамый, хөкем сөрү вакыты төрлечә. Түбәнге палеолитны борынгы казылма кешеләр — палеоантроплар (австралопитеклар, питекантроплар) дәвере дип исәпләү кабул ителгән, ул чуерташтан эшләнгән хезмәт кораллары, кул кискечләре һ.б.ның өстенлек итүе б-н аерылып тора. Урта палеолит неандерталь тибындагы кешеләрнең таралуы һәм чакматаштан эшләнгән хезмәт коралларының (ярчыкларның) өстенлеге б-н үзенчәлекле. Татарстанда әлеге чорның иң борынгы истәлекләре — «Красная Глинка» тукталылыгы һәм Иделнең уңъяк ярында (Тәтеш р-ны терр-ясе) урнашкан торулыклар. Югары палеолит хәзерге типтагы кешеләр — кроманьонлылар һәм хезмәт кораллары ясауның




Измәр I палеолит туктаулыгы таш хезмәт кораллары.

пластинкалы-кисү техникасы барлыкка килү б-н бәйле. Бу чорга Тәтеш һәм Кама Тамагы р-ннары терр-ясендә һәм Кама тамагы тирәсендә урнашкан истәлекләр (Кама Тамагы II туктаулыгы, Сөйки Кичүе посёлогы янындагы торулык) карый. Мезолит өчен җәя барлыкка килү һәм пластинка, геом. формалы хезмәт кораллары киң таралу хас. Татарстан терр-ясендә мезолит *Чулман тамагы культурасы, Чулман буе культурасы* истәлекләрендә, ш.у. Кабык-Күпер II туктаулыгында чагыла (пластинкалардан һәм ярчыклардан эшләнгән хезмәт кораллары — балталар, өтергеләр, кыргычлар һ.б.). Неолит чорында таштан хезмәт кораллары ясау иң югары камиллек дәрәҗәсенә ирешә: кешеләр таш эшләнмәләрне шомарта, аларны тишә һ.б. техник операцияләр башкара беләләр. Татарстан терр-ясендә Т.г. истәлекләренең күпчелеге шул чорга карый: туктаулыклар, торак һәм хуҗалык корылмалары, шомартылган таш хезмәт кораллары, төрле керәч эшләнмәләр һ.б. (к. *Идел-Чулман культурасы*). Ширбәт II, Лебедино II (Спас р-ны) һәм Рус Әҗбие (Актаныш р-ны) туктаулыклары неолит культурасының эталон истәлекләре булып тора. Татарстан терр-ясендә Т.г. энеолит чоры б-н

тәмамлана — бакыр металлургиясе барлыкка килә, таш хезмәт кораллары б-н бергә бакыр хезмәт кораллары кулланыла башлый (к. *Волосово культурасы, Гарино-Бор культурасы*).

*Әд.:* Халиков А.Х. Древняя история Среднего Поволжья. М., 1969; Косменко М.Г. Мезолит Среднего Поволжья. М., 1971; шул ук. Основные этапы развития мезолитической культуры в Среднем Поволжье // Советская археология. 1972. № 3; Гладилин В.Н. Проблемы раннего палеолита Восточной Европы. К., 1976; Галимова М.Ш. Памятники позднего палеолита и мезолита в устье Камы. М., 1999.

*Р.С.Габәшев.*

**ТАШ ЧЫПЧЫКЛАРЫ́** (Oenanthe), чебенче кошлар семьялыгы, миләш чыпчыклары ассемьялыгыннан кошлар ыругы. 18 төре билгеле, Европа, Азия, Төньяк-Көнбатыш Африка һәм Төньяк Америкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади Т.ч. (O. oenanthe), ташлы токымнар чыгып торган далаланган участокларда яши. Күчмә кош. Апрельдә очып киләләр. Гәүдәсенең озынлыгы 20 *см* га кадәр, авырлыгы якынча 20 *г.* Соргылт-кара төстә. Күз төбеннән кара буй китә. Томшыгы нечкә, төбендә киң. Авыз почмакларында — вак төкчәләр. Аяклары кәчле, озынча. Койрыгы кыска, туры. Таш араларындагы балчыксыл кыя ярыкларында, кайвакыт йомран, әрлән өннәрендә яши. Коңгырт тимгелле 4–7 аксыл-зәңгәр йомырка сала. Бөҗәкләр, үрмәкүч, үсемлек орлыклары б-н туклана. Августта очып китәләр. Респ-каның көньяк р-ннарына кайвакыт Т.ч.ның якын төрләре — ак башлы Т.ч. (O. pleshanka) һәм сикергәк Т.ч. (O. isabellina) очып керә.

**«ТАШАЯ́К»**, Казанда 15–16 йөзләрдә һәрдаим эшләгән ярминкә. Кремль калкулыгыннан көньяктарак Болак ермагының уңъяк ярында урнашкан. Базар мәйданының үзәгендә таш касә (таш аяк) була, анда базар салымы җыела. «Т.»та Идел буе сәүдәгәрләре, Урта Азиядән, Кавказдан, Кырымнан һ.б.дан килгән сәүдәгәрләр сәүдә иткәннәр (күн, затлы мехлар, тукымалар, металлдан эшләнгән әйберләр һ.б. товарлар). Идел буеның төп ярминкәсе булып исәпләнгән. 18 йөздә — 20 йөз башында бу урында агачтан эшләнгән сәүдә рәтләре һәм кибетләр урнаштырыла, ел саен май–июнь айларында язгы биржа сатулары (ярминкәләре) үткәрелә. Казансу елгасында дамба һәм Куйбышев сусаклагычы төзелгәннән соң, рельеф тулысынча үзгәрә. Ташаяк урамының бер өлеше генә саклана.



Казанның «Ташаяк» ярминкәсендә сәүдә рәтләре. 20 йөз башы фоторәсеме.

*Әд.:* История Казани. К., 1988. Т. 1; Амиров К. Казань: где эта улица, где этот дом?: Справ. улиц города Казани. К., 1995.

**ТАШБАСМА́** (литография), басма форма буларак яссы таш, металл пластина өслеге кулланыла торган басма ысулы; *графика* төре, яссы гравюра. 19 йөз башыннан рәсемнәрне репродукцияләү өчен кулланыла һәм автор техникасы буларак үсеш ала. Франциядә киң тарала, пейзаж һәм карикатура, графика сәнгатенең иллюстрация һәм плакат төрләре үсешендә зур роль уйный.

Россиядә Т. 1820–40 елларда күренеш пейзажында, көнкүреш жанрында, портретта, иллюстрациядә киң тарала; 20 йөздә агитация плакатында актив файдаланыла, сәнгатьнең иң демократик һәм гаммәви төре буларак, натюрмортта, пейзажда, көнкүреш һәм портрет жанрларында, анималистик һәм тарихи жанрларда үсеш ала, китап графикасында киң кулланыла.

1830 елларда көнкүреш пейзажы жанрындагы Т.га Казан рәссамнары да мөрәҗәгать итә. Казан күренешләреннән торган альбомнар өчен биредә иҗат ителгән рәсемнәр, ташбасма җиһазлар булмау сәбәпле, башка шәһәрләрдә бастырыла; мәс., Казанга багышланган беренче альбом — В.С.Туринның «Губерна шәһәре Казанның натурадан ясалган күренешләре» («Перспективные виды губернского города Казани, рисованные с натуры...») — Мәскәүдә басыла (1834); чираттагы альбом — Э.Т.Турнереллиның «Казанның натурадан ясалган күренешләре...» («Виды Казани, рисованные с натуры...», Лондонда дөнья күрә (1839–40). Казан күренешләрен тасвирлау тәҗрибәсенә ш.у. А.Н.Ракович та мөрәҗәгать итә — шәһәрнең берничә һәйкәлен бер биттә сурәтли һәм аны 1853 тә Мәскәүдә бастырып чыгара.

19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында Т. Казанда, башлыча, репродукция техникасы буларак, китап һәм газета-журнал графикасында кулланыла. Озак вакытлар буена традицион кульязма китап формаларын саклаган татар китабын бастыру эшендә Т. аеруча киң кулланыла. Ул текстларны да, еш кына типографик алымда җыелган текстка туры килгән орнамент бизәкләрен дә бастыруда файдаланыла. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында текстлардагы гарәп язуы мәчет күренешләре, геом. һәм үсемлек бизәкләре б-н бербөтен гармония тудырган ташбасма *шәмаилләр* киң тарала.

Сәнгати автор Т.сы (автоташбасма) үсеше 20 йөздә Казанда «*Всадник*» графика коллективы (1920–24) һәм аның җитәкчесе И.Н.*Плещинский* эшчәнлеге б-н бәйле. Ул пейзажлар, портретлар, немец экспрессионизмы стилендәге жанрлы композицияләрдән торган «Ташбасмалар (6 рәсем)» («Литографии (6 рисунков)», 1920) һәм «18 автоташбасма (рәсемнәрнең 2 нче циклы)» («18 автолитографий (2-й цикл рисунков)», 1921) аз тиражлы ташбасма альбомнарын чыгара һәм Т.ны китап бизәлешендә куллана. И.Н.Плещинский һәм Д.М.*Фёдоров* рафыннан «Н.Шикалов һәм М.Андреевскаяның күргәзмә каталогы» («Каталог выставки Н.Шикалова и М.Андреевской», 1921) тулы ташбасма китабы дөнья күрә. Т.га В.Э.*Вильковиская*, К.К.*Чеботарёв*, П.М.*Байбарышев*, С.С.Федотов та мөрәҗәгать итә. М.В.*Барашов* Т.да театр актёрларына дусларча шаржлар: «Казан рампасы янында» («Около Казанской рампы»), «Мастфор» альбомнары иҗат итә (икесе дә — 1923).

Гражданнар сугышы чорында һәм тыныч төзелешнең башлангыч елларында зур әһәмияткә ия булган Казан агитация плакаты күбесенчә Т.да башкарыла. Бу өлкәдә «Всадник» берләшмәсе зур роль уйный, аның әгъзалары (И.Н.Плещинский, Н.М.*Сокольский*, М.В.Барашов) плакат иҗат итүдә эскиздан алып басмага кадәрге барлык циклны графика остаханәсендә үзләре тормышка ашыралар. Казан хәрби плакатларының югары дәрәҗәсе Респ-каның Запас армиясе штабы ташбасмаханәсендә, атаклы рус совет сатирик плакаты һәм карикатура остасы В.Н.Денинның хезмәте б-н тәэмин ителә. Казан плакатларының күпчелеге дәүләт ташбасмаханәләрендә басыла, һәм биредә рәсемнәрне ташка күчерүче ташбасмачы осталыгы зур әһәмияткә ия була. Литографлар П.А.Зверев һәм А.В.Бутин әлеге өлкәгә зур өлеш керткән осталардан санала.


1920 еллар уртасында Т. Казан архит-ра-техника ин-тының графика остаханәсе (1935 тән — Казан сәнгать уч-щесе) көчләре б-н, башлыча, басма рәсем жанрында (Г.И.Сотонина, В.А.Бадюль, А.И.Иорданский һ.б.) һәм 1920 елларның 2 нче яртысы татар рәссамнары (М.З.Кәримов, М.Б.Рәхмәтуллин, Х.А.Алмаев) иҗатында үсеш ала. 1930 еллар башында, ташбасма җиһазлар юкка чыгарылгач, Казандагы автор Т.сы үсеше берничә дистә елга өзелә.

Соңрак, 1970–80 елларда, Казан графиклары СССР Рәссамнар берлегенең «Челюскинская» иҗат йортында Т. әсәрләр иҗат итәләр. Казан автоташбасма осталары М.К.*Мавровскаяның* («Горький Казанда» («Горький в Казани», 1982), «Идел ярлары буйлап» («По берегам Волги», 1987), «Студент Володя Ульянов Казанда һәм Кокушкинода» («Студент Володя Ульянов в Казани», 1988) серияләре), И.К.*Колмогорцеваның* («Рус халык мәкальләре» («Русские народные пословицы», 1971), «Балачак бәйрәмнәре» («Детские праздники», 1984) серияләре; Г.Тукайга, А.Пушкинга, М.Цветаевага багышланган цикллар, 1980 еллар) Т. битләре нәкъ менә шунда басыла. Н.Д.Кузнецов («Гигант-могҗиза» — «Чудо-гигант», 1971), А.Р.Туманов («Улым портреты» — «Портрет сына», 1970), М.И.Кузнецов («Балачак» — «Детство» сериясе), 1985), Ә.Р.*Ильясова* («Тәмле йокы», 1992; «Пегас», 1992), Р.Ш.*Зиннәтова* («Туган як җыры» сериясе, 1980) автоташбасма һәм төсле ташбасма әсәрләр иҗат итәләр.

Т. ысулы б-н төрле продукция: китаплар, эстамп, плакат, игъланнар, чакыру билетлары һ.б. басуга җайлашкан пр-тиеләр яки цехлар да ташбасмаханә дип атала. Казанда бе-













**Ташбасма**. 1. В.С.Т у р и н. «Казандагы Гостиный двор». «Губерна шәһәре Казанның ерактан күренеше...» альбомыннан. Ташбасма. 1834; 2. Э.Т.Т у р н е р е л л и. «Татар җамигъ мәчете». «Казан күренешләре» альбомыннан ташбасма. 1839; 3. «Казан кальгасы күренеше» (В.С.Турин оригиналыннан). И.С.Перов төсле ташбасмасы. 1885; 4. Шәмаил. Төсле ташбасма. Казан университеты басмаханәсе. 1899. ТР Милли музее; 5. Шәмаил. Төсле ташбасма. В.В.Вараксинның типохром ташбасмасы. 1904; 6. Мөхәммәтҗан Х у җ а с ә и д о в. «Нух пәйгамбәрнең икенче көймәсе». Шәмаил. Төсле ташбасма. 1904. ТР Милли музее; 7. И.Н.П л е щ и н с к и й. «Профсоюзлар – җитештерү тоткасы». Казан сәнгать остаханәләре ташбасмасы. 1921; 8. Г.Й о с ы п о в. «Хатын-кыз портреты». Автоташбасма. 1929; 9. М.К.М а в р о в с к а я. «Казанның Алексей Пешков йөкче булып эшләгән элеккеге пристане». Ташбасма. 1979. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее; 10. М.И.К у з н е ц о в. «Балачак». Төсле ташбасма. 1985; 11. Р.Ш.З и н н ә т о в а. «Кәҗә сауганда». Автоташбасма. 1980; 12. Ә.Р.И л ь я с о в а. «Тәмле төш». Тоныкландырылган ташбасма. 1992. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.

ренче ташбасмаханә (яки тиешле җиһазлары булган басмаханә) 1843 тә Ш.*Яхин* тырышлыгы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Аның ташбасмаханәсендә шәмаилләр, календарьлар, дини әдәбият бастырыла. 1870 елларда Казан басмаханәләре ташбасма ташлары һәм станоклары б-н җиһазлана.

19 йөз ахырында — 20 йөз башында Казандагы китап басу эшендә һәм гамәли графикада Казан ун-ты ташбасмаханәсе, ш.у. хосусый ташбасмаханәләр (И.Перов, Тилли, М.Семёнов, В.Еремеев, А.Шашабрин, «Кокорев һәм К°») сизелерлек эз калдыра. Бертуган Кәримовларның басмаханә-ташбасмаханәсе 20 йөз башында шәмаилләр бастыра. И.Н.Харитонов, В.В.Вараксиннарның басмаханә-хромоташбасмаханәләре 20 йөз башында Россиянең югары сәнгати һәм полиграфик дәрәҗәдәге төрле басмалар чыгаручы иң яхшы ташбасмаханәләрдән санала. Ш.у.к. *Гравюра, Графика.*

*Әд.:* Дульский П.М. Книга и её художественная внешность (в связи с казанским книгопечатанием). К., 1921; шул ук. Казанские современные графики // Гравюра и книга. 1925. № 1–2; шул ук. Оформление татарской книги за революционный период. К., 1930; Корнилов П.Е. Казанский плакат. К., 1929; шул ук. Художественные издания Казани за 10 лет (1917–1927 гг.). К., 1930; Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; Червонная С.М. Искусство Советской Татарии. М., 1978; Шамаили из коллекции Национального музея Республики Татарстан (конец XIX — начало XX вв.). Собр. проф. И.М.Покровского и Н.Ф.Катанова: Альбом. К., 2003; Вербина О.Г. Живая летопись Казани в искусстве старых мастеров // Казань. 2005. № 7/8.

*О.Л.Улемнова.*

**ТАШБА́Ш БАЛЫКЛА́Р** (Gobiidae), алабугасыманнар отрядыннан балыклар семьялыгы. 600 гә якын төре билгеле. Тропик һәм уртача киңлектәге диңгезләрнең яр буе өлешләрендә, ш.у. тозлырак һәм төче сулыкларда таралган. ТР терр-ясендә 2 төре бар. Куйбышев сусаклагычына йолдызлы карачкы балык (Benthophilus stellatus) Дон елгасының түбәнге агымыннан кертелгән, йомры ташбаш (Gobius melanostomus) Идел елгасының түбәнлекләреннән кергән. Озынлыгы 20 *см* га кадәр. Яньчек гәүдәле. Т.б.га корсак йөзгечләренең өлешчә яки тулысынча кушылуы хас. Йомры ташбашның түбәсе һәм баш арты эре тәңкәләр б-н капланган; алгы сырт йөзгечендә зур кара тап бар; йолдызлы карачкы балыкның тәңкәләре юк; гәүдәсе бик күп төерчекле, сыртында аркылы өч кара сызык сузылган. Уылдыгын җәй буе ояларга сала. Су төбендәге умырткасызлар б-н туклана. Кәсәбәчелек өчен әһәмияте юк.

**ТАШБАШЛА́Р** (Gobio), карплар семьялыгыннан балыклар ыругы. 20 гә якын төре билгеле, Евразиянең төче сулыкларында таралган. ТР терр-ясендә бер төре бар: гади Т. (G. gobio) Идел, Кама һәм аның кушылдыкларында яши. Озынлыгы 15–20 *см*, авырлыгы 25 *г.* Гәүдәсе озынча, уклаусыман; өсте яшькелт-коңгырт, ян-яклары көмешсыман, зәңгәрсу яки карасу тимгелләр б-н капланган, кайвакыт алар тоташ кара буй хасил итәләр; корсагы көмешсыман. Башы чагыштырмача зур, танавы төшебрәк тора. Тәңкәсе эре. Авыз почмакларында мыекчыклар урнашкан. Яшәвенең 3–4 нче елында җенси җитлегә. Үрчемлелеге — 3 мең уылдык бөртеге. Май аеннан июльгә кадәр уылдык чәчә. Уылдыкны комсу-вак ташлы грунтка өлешләп сала, алар анда ябышып кала. Су төбендә яшәүче бөҗәк личинкалары, кысласыманнар, моллюсклар һәм суүсемнәр б-н туклана. 6–8 ел яшиләр. Кәсәбәчелек өчен әһәмияте юк. Балык тоту спортында ерткыч балыкларны аулау өчен җим буларак кулланыла.

**ТАШБИЛГЕ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 8 *км* көньяктарак, Актай елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 412 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 14 йөздә үк хәзерге Т. урынында авыл була, берара ул ташландык хәлдә кала, 17 йөзнең 2 нче яртысында яңадан халык килеп урнаша. Рус чыганакларында Починок Ташпилик, Смолкино исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, бакалея-мануфактура кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2167,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Әлки волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 92 ир-ат; 1859 да — 749, 1897 дә — 1066, 1908 дә — 926, 1920 дә — 1390, 1926 да — 751, 1938 дә — 636, 1949 да — 410, 1958 дә — 464, 1970 тә — 564, 1979 да — 413, 1989 да — 422, 2002 дә — 417 кеше. Т. тирәсендә 14 йөзнең эпиграфик истәлекләре — таш каберлекләр сакланган.

**ТАШБУЛА́ТОВ** Илдар Габдулла улы (22.10.1925, Кара-Кыргыз авт. өлкәсе, Алма-Ата ш. — 27.2.1997, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан пед. ин-тын (1958), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1961) тәмамлый. 1951–54 елларда ВЛКСМның Казан шәһәре Дзержинский район ком-ты 1 нче секретаре. 1954–58 дә КПССның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы, сектор мөдире, бүлек мөдире урынбасары. 1961–63 тә КПССның Казан шәһәр ком-тында бүлек мөдире. 1963–67 дә КПССның Казан шәһәре Совет район ком-ты 1 нче секретаре. 1967–79 да ТАССР азык-төлек министры. 1979–88 дә ТАССР МС Рәисе ярдәмчесе. 1967–80 дә ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Октябрь Революциясе, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**ТАШКАБА́К** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 22 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы ярындагы пристань. 2010 елда 44 кеше (руслар) яши. Башлангыч мәктәп. 17 йөз башында сарай җирләрендә нигезләнә, 1693 тә К.А.Нарышкин хуҗа була. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, бакчачылык б-н; таш, известь, алебастр һәм гипс чыгару, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.та волость идарәсе урнаша; Покров чиркәве (1736 да төзелә); земство мәктәбе (1886 да ачыла), телефон пункты, тимерчелек, җил тегермәне, 2 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 701 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ташкабак волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 267 ир-ат; 1859 да — 423, 1897 дә — 390, 1908 дә — 425, 1920 дә — 460, 1926 да — 542, 1938 дә — 508, 1949 да — 360, 1958 дә — 390, 1970 тә — 234, 1979 да — 159, 1989 да — 117, 2002 дә — 84 кеше.

**«ТАШКА́Й»**, татар халкының качкыннар турындагы тарихи җыры. Татар-мишәрләр арасында киң таралган. Җырның авторы — Ташкай (Ташмөхәммәт) исемле кеше. Чын биографик фактларга нигезләнгән. Үзсүзле кеше буларак, Ташкай патша законнарына, җирле байларга буйсынмый, шуның өчен Себергә сөрелә. Кача. Урманнарда яшеренеп яши, әмма кабат тотыла. Җырда каңгырап йөрүче качкынның авыр тормышы тасвирлана. Җыр ахырында Ташкайның үзен әзәрлекләүчеләргә карата нәфрәте һәм үч алу теләге чагыла. Караңгы төннәр һәм кара урманнар «Т.»дагы драматик вакыйгаларның сәнгати фоны булып хезмәт итә.

Җырның ике варианты билгеле — беренчесе — 1958 елда Горький өлкәсенең Камка авылында Х.Х.Ярмөхәммәтов (Х.Х.Ярми) тарафыннан, икенчесе («Дашкай») 1962 дә Горький өлкәсенең Сергач р-нында И.Н.Надыйров һәм Ф.В.Әхмәтова тарафыннан язып алына. Беренче тапкыр «Т.» Х.Х.Ярмөхәммәтов тарафыннан «Бәетләр» (1960) җыентыгында нәшер ителә. Кульъязмалары ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының фольклор фондында саклана.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. К., 1988; Урманче Ф. Тарихи җырлар // Татар халык иҗаты: Дәреслек. К., 2005.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ТАШКЕ́НТ КӘРВАНЫ́**, Россия сәүдә кәрваны (1741–42). Кәрван, 1735 елда Оренбург кальгасы (хәзерге Орск ш.) нигезләнгәннән соң, Россия б-н Урта Азия арасында сәүдә мөнәсәбәтләрен урнаштыру максатыннан оештырыла. 1738 дә Оренбургтан киткән кәрван талана. 1741 дә төбәктән яңа кәрван — «Т.к.» озатыла. Аның составы зур булмый: татар сәүдәгәрләре Ш.*Арсланов*, М.*Йосыпов*, С.Дроздовтан (үз хезмәтчеләре һәм озата баручылары б-н) тора. Кәрван казакъ җирләре аша хәрәкәт итә. Тургай елгасы тирәсендә Дроздов, аннан соң аның хезмәтчесе З.Салтанаев һәлак була. Т.к.на берничә тапкыр талау куркынычы яный. Төркестан шәһәре (хәзер Казакъстан Респ-касы) юлда мөһим пункт


булып тора, анда Арсланов һәм Йосыпов үз товарларының бер өлешен җирле постауга, күнгә һ.б.га алыштыралар. Соңыннан Олы Жүздән Түлә би ярдәме б-н кәрван Ташкентка барып җитә. Сәүдә эшләреннән әллә ни файда күрмичә, шәһәр идарәчесе Күсәк бәкнең начар мөнәсәбәтен тоеп, Арсланов һәм Йосыпов Ташкенттан китәләр. Т.к.ның бер нәтиҗәле ягы шунда: Урта Азиядән Россиягә сәүдә кәрваны килә (700 ләп кеше).

*Әд.:* О г л о б л и н Н. Путешествие русских купцов в Ташкент. 1741–1742 // Рус. архив. 1888. Кн. 2, вып. 8. *И.Р.Вәлиуллин.*

**ТАШКЕ́НТ ТАТА́Р ТЕА́ТРЫ**. Ташкентта татар телендә беренче спектакльләр 20 йөз башында генерал Еникиев һәм галим-этнограф А.Диваев йортларында куела. «Сәйяр», «Нур» труппаларының гастроль чыгышлары татар театр түгәрәкләре оешуга булышлык итә. 1918 елның апрелендә «Туран» мәдәни-агарту оешмасы каршында даими татар труппасы барлыкка килә, ул «Бәхетсез егет», «Бүләк өчен», «Уйнаш» (Г.Камал), «Төркестан табибе» (М.Уйгыр) спектакльләрен куя. 1919 ның августында әлеге труппа җирлегендә С.Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин» пьесасы буенча куелган спектакль б-н Өлкә татар театры ачыла; баш режиссёры — Ф.Бакиров, труппа составында — Н.Сакаев, Н.Таждарова, Ф.Ильская, Камал I, Ф.Камалова. Репертуарын Г.Камал, Г.Коләхмәтов, М.Фәйзи, Я.Вәли, С.Рәмиев, Г.Кариев, Ф.Бурнаш, ш.у. җирле авторлардан Госмани («Безнең каһарманнар»), Рәхмәт («Революция корбаннары») пьесалары тәшкил итә. 1920 дә, актёрларның бер өлеше Казанга күчеп китү сәбәпле, театр ябыла; калган актёрлар үзбәк театрына күчә. 1936 да Татар дәүләт театры буларак яңадан ачыла; сәнгать җитәкчеләре — Исхак Иллялов, аннары Ш.Шамильский, рәссамы С.Борындыков була. Труппага Н.Аитова, Н.Әбүзәрова, Р.Галикәева, А.Казанская, Р.Кәтиева, Р.Урманцева, Н.Мамин, Ф.Сәйфетдинов, Һ.Солтанов, З.Туишев керә. Театр репертуарында «Банкрот», «Беренче театр» (Г.Камал), «Зәңгәр шәл», «Кандыр буе» (К.Тинчурин), «Галиябану» (М.Фәйзи), «Наёмщик», «Кыю кызлар», «Чаткылар» (Т.Гыйззәт), «Шәмсекамәр» (М.Әблиев), «Урманда» (Ф.Хөсни) спектакльләре урын ала. Бөек Ватан сугышы елларында театр эшләми, 1947 дә Ташкент өлкә татар муз. драма театры буларак эшли башлый. 1949 да эшчәнлеге туктатыла.

*Әд.:* И л я л о в а И. Межнациональные связи татарского театра. К., 1985. *И.И.Илялова.*

**ТАШКИРМӘ́Н** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 65 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 499 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, балык тоту. Урта мәктәп, мәдәният йорты. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балык тоту, тимерчелек, дилбегә үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.дә волость идарәсе урнаша; Гурий чиркәве (1895–1914; архит-ра истәлеге), Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе (1869 дә Изге Гурий борадәрлеге ача, 1875 тә министрлык карамагына бирелә), 3 тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1975 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Саралы волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 193 ир-ат; 1859 да — 835, 1897 дә — 1220, 1908 дә — 1341, 1920 дә — 1444, 1926 да — 1526, 1938 дә — 954, 1949 да — 643, 1958 дә — 634, 1970 тә — 563, 1979 да — 584, 1989 да — 549, 2002 дә — 552 кеше. Т. янында *Ташкирмән комплексы* урнашкан.



Ташкирмән авылы. Изге Гурий чиркәве. 1914.

**ТАШКИРМӘ́Н КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Лаеш р-нының Ташкирмән һәм Макаровка авыллары янында Мишә елгасының (Кама елгасының уң кушылдыгы) уң ярында урнашкан. Т.к. истәлекләре 1871 елда А.Н.Стоянов, 1948 дә Н.Ф.Калинин, 1960–80 дә А.М.Ефимова, А.Х.Халиков, П.Н.Старостин һ.б. тарафыннан тикшерелә. Бронза гасыр торулыкларын, 5 авыллык, 2 шәһәрлекне («Кала Баш», «Бишек Кала») һәм Имәнкискә археол. культурасына нисбәтле каберлекне, Болгар археол. культурасына караган авыллык һәм каберлекне үз эченә ала. Шәһәрлекләрнең иң зурысы — «Кала Баш»: аның мәйданы 0,6 *га* чамасы, ул биеклеге 6 *м* га якын, нигез киңлеге 10 *м* лап булган ныгытма б-н сакланган. Дивар калдыкларына караганда, башта ул балчык сыланган агач каркастан салынган, соңыннан яндырып чыныктырылган («Таш кирмән» — «Таш крепость» һәм Ташкирмән авылы атамалары шуннан килә). Шәһәрлекнең культура катламының калынлыгы 1 *м* га якын, анда Имәнкискә культурасына нисбәтле керамика табыла. Шәһәрлек читендә Имәнкискә авыллыгы (стена корылмасы һәм керамика чыккан урын б-н ярымземлянка калдыклары) һәм каберлек ачыклана. Ачылган каберләрнең берсендә җирләү кечерәк кенә квадрат чокырда мәетләрне яндыру йоласы б-н башкарылган, чокыр төбенә чүлмәк рәвешендәге яссы төпле әвәләп эшләнгән балчык савыт куелган; икенчесендә — зур чокырда (мәет аркасында ята, кул-аяклары гәүдә янында тарттырылган) ингумация йоласы буенча уздырылган, гәүдә сөякләрендә бронза аеллар, тимер без һәм кечерәк пычак; мәетнең аскы очлыклары янында ат аяклары һәм баш сөякләре, 3 яссы төпле савыт табыла. «Кала Баш»тан ерак түгел ш.у. болгар авыллыгы һәм җирләү мөселман йолалары б-н башкарылган каберлек булуы ачыклана. «Бишек Тау» шәһәрлеге озынлыгы 20 *м* га, киңлеге 7–8 *м* га якын зур булмаган борында урнашкан була, кыр ягыннан конус рәвешендәге туфрак вал (биеклеге 1,5 *м* чамасы) б-н сакланган. Шәһәрлектән ерак түгел болын өсте террасасы читендә авыллык булган.

*Әд.:* Археологическая карта Татарской АССР. Предкамье. М., 1981; К а з а к о в Е.П., С т а р о с т и н П.Н., Х а л и к о в А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987; С т а р о с т и н П.Н. Ташкирменьский могильник // Памятники древней истории Волго-Камья. К., 1994. *П.Н.Старостин.*

**ТАШКИ́Ч** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 27 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кесмәс елгасы буенда. 2010 елда 183 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1678 дән Кесмәс елгасы буендагы авыл исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 532,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 52 ир-ат; 1859 да — 312, 1897 дә — 3446, 1908 дә — 346, 1920 дә — 433, 1926 да — 544, 1938 дә — 398, 1949 да — 340, 1958 дә — 305, 1970 тә — 309, 1979 да — 237, 1989 да — 176, 2002 дә — 198 кеше.

**ТАШКИЧҮ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 33 *км* төньяктарак, Ашыт елгасы буенда. 2010 елда 395 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле – кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 дән Ташкичү елгасы буендагы Пүчинкә исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Кадайгулово, Кудайгуловская Пустошь буларак та мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, чыпта сугу, башмак тегү, тимерчелек, сәүдә, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1817 дә төзелә; архит-ра истәлеге; 1821–56 да Ш.*Мәрҗанинең* әтисе Б.Мәрҗани имам-хатип булып тора), мәдрәсә (шәкертләре арасында *Батырша* да бар), 1 җил һәм 2 су тегермәне, тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2573,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 164 ир-ат; 1859 да — 885, 1897 дә — 803, 1908 дә — 974, 1920 дә — 977, 1926 да — 861, 1938 дә — 863, 1949 да — 588, 1958 дә — 578, 1970 тә — 526, 1979 да — 441, 1989 да — 395, 2002 дә — 399 кеше.

**ТАШКИЧӨ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 29 *км* көнбатыштарак, Карлы елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 476 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Чепкас исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә; лашманлыкта эшли, игенчелек, терлекчелек, тегү б-н шөгыльләнә, вак-төякләр б-н сәүдә итә. 20 йөз башында Т.дә мәчет, мәдрәсә, янгын сүндерү станциясе эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1590,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Янтуган волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 октябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 509, 1880 дә — 648, 1897 һәм 1913 тә — 714 әр, 1920 дә — 879, 1926 да — 810, 1938 дә — 781, 1949 да — 775, 1958 дә — 720, 1970 тә — 821, 1979 да — 948, 1989 да — 539, 2002 дә — 541 кеше.

**ТАШКИЧӨ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 24 *км* төньяктарак, Бола елгасы буенда. 2010 елда 192 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, иткә терлек асрау. Урта мәктәп, клуб. Мәчет. 1646 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.дә мәчет, мәдрәсә, җил тегермәне, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1560,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Черки-Килдураз волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. Халык саны: 1782 дә — 93 ир-ат; 1859 да — 561, 1897 дә — 709, 1908 дә — 815, 1920 дә — 854, 1926 да — 632, 1938 дә — 670, 1949 да — 463, 1958 дә — 448, 1970 тә — 457, 1979 да — 648, 1989 да — 229, 2002 дә — 238 кеше.

**ТАШКИЧӨ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 23 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Чаллы–Сарман автомобиль юлы буенда. 2010 елда 200 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1881 дә нигез салына. Халкы игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.дә мәчет, мәктәп, тимерчелек, ашлык саклау-сату һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2453,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1897 дә — 609, 1920 дә — 907, 1926 да — 601, 1938 дә — 668, 1949 да — 428, 1958 дә — 368, 1970 тә — 350, 1979 да — 295, 1989 да — 205, 2002 дә — 200 кеше.

**ТАШКИЧӨ́** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Әтәмби елгасы буенда. 2010 елда 157 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1924 тә нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Бәйрәкә волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1926 да — 297, 1938 дә — 370, 1949 да — 407, 1958 дә — 326, 1970 тә — 290, 1979 да — 234, 1989 да — 160, 2002 дә — 172 кеше.

**ТАШКИЧӨ́ МӘЧЕТЕ́**, Арча р-нының Ташкичү авылында, архит-ра истәлеге. 1817 елда Казан сәүдәгәре Сөләйман ибне Назир акчасына төзелә. Икенче катындагы намаз заллары анфилада стилендә планлаштырылган ике катлы, турыпочмаклы бина. Мәчет ишеге төньякта урнашкан. Көнбатыш фасадтагы ишекләр хуҗалык-склад биналарына илтә. Намаз заллары калын дивар б-н бүленгән (элек анда чарлакка һәм манарага алып менүче тар баскыч булган) һәм көнбатыштан дүрт



Ташкичү мәчете. 1817.

тәрәзә, көнчыгыштан өч тәрәзә б-н яктыртылган. Төп намаз залының көньяк диварында ш.у. өч тәрәзә уелган. Мәчетнең штукатурланган фасадлары кырыс классицизм стилендә чишелеш тапкан. Буй фасадлар тимпанында ярымтүгәрәк уемлы өчпочмаклы фронтон б-н тәмамланган 3 тәрәзәле үзәк ризалит аерылып тора. Беренче һәм икенче катлардагы ризалитның үзәк «сукыр» тәрәзәсе заллар арасындагы калын аркылы дивар турышына туры килә. Икенче каттагы тәрәзә өсләрендәге фигуралы кронштейннарга шәкелле кәрнизләр куелган. Ике кат арасындагы һәм тәрәзә астындагы чыгынтылары б-н фасадлар очындагы шәкелле кәрниз бинаның кырыс бизәлешен тулыландыра. Түбә үзәгендәге манара 1930 да киселә; арх. Р.В.Билалов проекты буенча торгызыла. Үзенең традицион күләм-планлаштыру чишелеше һәм фасадларының стилистик бизәлеше буенча Т.м. Казандагы Иске Таш мәчет һәм 11 нче мәчеткә охшаган.

1821–56 елларда мәчетнең имам-хатибы Баһаветдин ибне Сөбхан әл-Мәрҗани була; мәчет каршындагы мәдрәсәдә аның улы Ш.*Мәрҗани* башлангыч белем ала.

*Әд.:* Мечети Татарстана / Сост. Х.Г.Надырова, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хайрутдинов. К., 2000.

*Х.Г.Надыйрова.*

**ТАШКӨ́Ш**, татар халкының флейтага охшаш тынлы музыка уен коралы, окарина тәреннән (итальян теленнән ocarina — каз бәпкәсе). Яндырылган кызыл яки ак балчыктан ясалган кош (күбесенчә күгәрчен, үрдәк, тавык, әтәч, кәккүк) рәвешендәге эче куыш савыт. Т.ның тараеп килгән аскы өлешендә сызгырту җайланмасы бар. Аның 2 дән алып 8 гә кадәр төрле зурлыктагы бармак тишеме була, алар уен коралының ике ягына да урнаша. Т.ның үлчәмнәре: биеклеге — 30–85 *мм*, озынлыгы — 45–120 *мм*. Т. ясау йолалары чүлмәк ясау производствосы б-н бәйле (әлеге музыка уен коралларын чүлмәкчеләр ясаган һәм базарларда саткан). Талантлы музыкантлар, Т. мөмкинлекләреннән оста файдаланып, анда төрле импровизация көйләре башкарганнар. Т.ның тавыш диапазоны аның зурлыгына, бармак тишемнәренең санына һәм аларның урнашуына бәйле. 2 бармак тишеме булган уен коралында — 3 аваз, 7 тишемлесендә 8 гә кадәр аваз (октава) чыгарырга була. Т. киң динамик (pp-ff) мөмкинлекләре булган ачык яңгырашлы аваз чыгара. Аваз чыгаруы тотрыклы. Хәзерге вакытта 6–8 бармак тишемле Т.лар тәҗрибә куючы осталар тарафыннан эшләнә, алар фольклор ансамбльләрендә соло музыка уен коралы буларак файдаланыла.

*Р.Ф.Халитов.*

**ТАШКУРА́Н** (Saxifraga), ташкуранчалар семьялыгыннан бер- яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 370 кә якын төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача һәм салкын поясларында таралган. ТР терр-ясендә бер төре — саз Т.ы (S. hirculus) бар. Кама аръягында очрый. Торфлы сазлыкларда үсә. 10–30 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамырлары нәзек. Сабагы туры, өске өлеше җирәнсу төкчәле, асты шома, төбеннән үк озын нәзек шуышма ботаклы. Яфраклары ланцетсыман, бөтен читле, аскылары сабакчалы. Чәчәкләре ак, сары төстә, себеркәч чәчәк төркемендә. Җимеше — бүлемнәр буенча ачылучы тартмачык. Июль–августта чәчәк ата. Орлыктан, тамырчалардан үрчи. Халык медицинасында тамыр һәм орлыклары тире авырулары вакытында, бәвел кудыру чарасы буларак кулланыла. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ТАШКҮМЕ́Р СИСТЕМАСЫ́ (ЧОРЫ́)**, карбон, абс. яше 360–300 млн. ел булган палеозой эратемасының бишенче системасы. Т.с.(ч.) башында материкларның шактый өлешен диңгез каплый һәм аларда мәрҗән, моллюсклар, борынгы балыклар (селахияләр) һ.б. киң таралганнар. Коры җирдә беренче җир өсте умырткалылары — стегоцефаллар, зур бөҗәкләр, урман һәм сазлыкларның беренче тереклек ияләре — гигант бакаларны, кәлтәләрне хәтерләтүче амфибияләр, зур рептилияләр күренә башлый. Үсемлекләр арасында агачсыман абагалар, плаунчалар өстенлек итә, беренче ылыслар барлыкка килә; агачлар 30 *м* биеклеккә һәм 1 *м* киңлеккә җитә, ботаклары аз (сигилярияләр) яки ботаклыраклар (лепидодендроннар). Донбасс, Кузбасс, Рур (ГФР), Аппалач (АКШ) һ.б. ташкүмер чыганакларының нигезен шушы үсемлекләр тәшкил итә. Татарстанда төп күмер чыганаклары шул вакытта барлыкка ки-

лә. ТР терр-ясендә Т.с.(ч.) утырмалары 300–2000 *м* тирәнлектә барлык җирдә дә үсеш алганнар, 3 бүлектән 7 ярустан торалар. Карбонның иң борынгы утырмалары (Турне ярусы) мәрҗән, брахиопода, фораминифера һәм балчык, мергель, доломит катламнары катыш известьташлардан гыйбарәт. Ярусның калынлыгы 30–500 *м*. Өстәрәк ятучы Визе ярусының түбәнге өлеше конгломерат, күмерле сланец катламлы комсу-балчыксыл токымнардан һәм ташкүмер ятмаларыннан тора. Ярусның югары өлешендә һәм Серпухов ярусының өстәрәк ятучы катламында известьташлар, кремний һәм ангидрит оялары булган доломитлар өстенлек итә. Ярусның калынлыгы 500 *м* дан артык. Башкорт, Мәскәү, Касыйм һәм Гжель яруслары известьташ, балчык, алевролит катламлы доломит, алевролит, гипс һәм ангидрит линзаларыннан тора. Бу ярусларның гомуми калынлыгы 600 *м* дан артык. ТРда Т.с.(ч.) токымнары җылы, чагыштырмача сай диңгез шартларында барлыкка килгән; тамыраяклар, мәрҗәннәр, диңгез лаләләре, диңгез керпеләре һ.б. бу процесста зур роль уйныйлар. Файдалы казылмалар: нефть, газ, ташкүмер, минераль сулар формалашу Т.с.(ч.) утырмалары б-н бәйле.

*Әд.:* Методическое руководство по поискам, оценке и разведке месторождений твёрдых нерудных полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999. Ч. 1. *Ю.В.Сементовский.*

**«ТАШКЫ́Н»**, Актаныш р-нындагы а.х. пр-тиесе, ҖЧҖ. 2003 елда Шәймәрданов исем. к-з җирлегендә оештырыла. Аның составына Иске Байсар (үзәк утары), Яңа Байсар, Чишмәбаш, Чиялек авыллары керә. А.х. җитештерүендә 97 кеше эшли. Хуҗалыкның төп тармаклары — бөртекле ашлык, сөт, ит җитештерү. 2013 тә 4702 *га* (ш.и. 2287 *га* пай) арендага алынган а.х. җирләре, 1888 баш мөгезле эре терлек (ш.и. 450 сыер) асрала. 56702 *ц* бөртекле ашлык, 26718 *ц* сөт, 2540 *ц* ит җитештерелә; бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 38,3 *ц*, уртача һәр сыердан еллык савым 5940 *кг*. Пр-тие җитәкчесе — Р.С.*Салихҗанов* (2003 тән).

**ТАШЛЫ́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 92 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бимә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 241 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1808 еллар тирәсендә Бима авылыннан күченүчеләр нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, төрле урманчылык кәсебе б-н көн итә. 20 йөз башында Т.да тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 264,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Бима волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1927 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1811 дә — 16 ир-ат; 1859 да — 167, 1890 да — 246, 1920 дә — 471, 1926 да — 523, 1938 дә — 467, 1949 да — 488, 1958 дә — 433, 1970 тә — 416, 1989 да — 253, 2002 дә — 247 кеше.

*Әд.:* Мәрданов Р.Ф., Һадиев Н.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**ТАШЛЫ́** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 14 *км* төньяктарак, Дим елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 115 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да мәчет, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2600 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Александровка волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1816 да — 61 ир-ат; 1859 да — 352, 1889 да — 572, 1897 дә — 723, 1910 да — 955, 1920 дә — 1017, 1926 да — 771, 1938 дә — 542, 1949 да — 416, 1958 дә — 379, 1970 тә — 396, 1979 да — 315, 1989 да — 182, 2002 дә — 151 кеше.

**ТАШЛЫ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 6 *км* көнбатыштарак, Ушма елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 39 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1652 дән мәгълүм. Башта авыл Зөя шәһәрендәге Успенье монастыре карамагында була, 1764 тә халкы — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да земство мәктәбе (1904 тә ачыла), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1176,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кызылтау волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 155 ир-ат; 1859 да — 500, 1897 дә — 520, 1908 дә — 622, 1920 дә — 558, 1926 да — 538, 1938 дә — 292, 1949 да — 200, 1958 дә — 160, 1970 тә — 125, 1979 да — 81, 1989 да — 43, 2002 дә — 43 кеше.

**ТАШЛЫ́ ЕЛГА́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 27 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кәркәүч елгасы буенда. 2010 елда 390 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Е.да мәчет, мәктәп, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 989,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Лыябаш-Келәүш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 45 ир-ат; 1859 да — 482, 1897 дә — 764, 1908 дә — 844, 1920 дә — 951, 1926 да — 992, 1938 дә — 400, 1949 да — 334, 1958 дә — 550, 1970 тә — 570, 1979 да — 445, 1989 да — 374, 2002 дә — 379 кеше.

**ТАШЛЫ́ ЕРЫ́М**, геол. табигать истәлеге. Идел елгасының уңъяк ярында, Югары Ослан р-ны Печище авылы янында. Печище ермагының түбәнге уңъяк тармагы. Югары Пермь системасы өске Казан асъярусының Печище халыкара стратотибының аерылгысыз өлеше булып тора (к. *Печище геологик киселеше*). 1986 елда билгеләнә. Мәйданы 12 *га*. Иң түбәнге Казан яны катламнарыннан кала, Т.е.да өске Казан асъярусы киселеше тулысынча диярлек ачыла (әлеге киселешне беренче булып тасвирлаган Н.Э.Ноинский терминологиясе буенча «эре» һәм катламлы ташлар). Ерымның каньонсыман тамак өлешендә Печище катламнары (астан өскә таба) — балчыксыл-мергельле катлам (1,5 *м*); целестин кристаллары һәм диңгез фаунасы калдыклары, «соры таш» җыелмаларыннан оолитлы доломит һәм известьташ (6 *м* га кадәр); гипс катыш юка катламлы доломитлар



Ташлы ерым.
Югары Казан асъярусы ачылмалары.

(3 *м* га кадәр) чыгып тора. Өстәрәк ятучы Югары Ослан катламнары чагыштырмача йомшак балчыксыл-мергельле «опока» җыелмаларыннан (якынча 9 *м*) башлана. Биредә ерым шактый киң, ярлары сөзәк, күп урыннар кәсле, чишмәләр күп. Ерымның югары өлеше Югары Ослан калкулыгында, биредә Югары Ослан катламнарындагы карбонатлы җыелмалар һәм Моркваш катламнарындагы балчыксыл-мергельле җыелмалар су б-н юылып ашалалар.

Т.е. терр-ясендә фәнни экскурсияләр, Казан югары уку йортларындагы табигыять белеме ф-ты студентларының практик укулары үткәрелә.

*Әд.:* Ноинский Н.Э. Разрез пермской толщи, выступающей на правом берегу р. Волги близ с. Печищи против г. Казани // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1899. Т. 13, № 6. *Б.В.Буров.*

**ТАШЛЫ́ КАВА́Л** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 23 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шәмәк елгасы буенда. 2010 елда 268 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле – кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысына кадәр нигез салына. 18 йөздә Кавал

авылы Югары Кавал һәм Түбән Кавал авылларына бүленә (1930 елларда Т.К. булып берләшәләр). 1865 тә, янгын чыгу сәбәпле, Югары Кавал авылы тулысынча янып бетә, халкы башка җиргә күчерелә. Авыл рәсми булмаган чыганакларда Яңа Кавал дип, Түбән Кавал исә Иске Кавал дип йөртелә башлый. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында ике авыл халкы да дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, кирпеч сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Югары һәм Түбән Кавалда 2 мәчет (1842 һәм 1902 дә төзелә), мәктәп, су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 732 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Дөбъяз р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: (мәгълүматлар 2 авылны да кертеп бирелә): 1782 дә — 153 ир-ат; 1859 да — 483, 1897 дә — 728, 1908 дә — 864, 1920 дә — 850, 1926 да — 935, 1938 дә — 1082, 1949 да — 971, 1958 дә — 1083, 1970 тә — 760, 1989 да — 254, 2002 дә — 277 кеше.

**ТАШЛЫ́ РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1935 елда оештырыла. Мәйданы — 3,4 мең *км*². Үзәге — Ташлы авылы (Оренбургтан 260 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 24881 кеше (1.1.2014). Татарлар саны: 1979 да — 1578, 1989 да — 1412, 2002 дә — 1580, 2010 да — 1314 кеше. Татарлар, башлыча, Бәшир, Иман-гол, Широкое авылларында яшиләр. Бәшир авылы мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла, авыл китапханәсе фондында татар язучылары китаплары саклана. Ташлы һәм Бәшир авылларында мәчет эшли. Т.р. терр-ясендә «Татнефть»-«Илекнефть» АҖ бүлекчәләре нефть чыганакларын табу б-н шөгыльләнә. Тел галиме Х.Х.*Мәхмүдовның* тормышы Т.р. б-н бәйле.

**ТАШЛЫ́К** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 15 *км* көньяктарак урнашкан. 2010 елда 409 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, яшелчәчелек, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет (1922 дә төзелә; архит-ра истәлеге). 1678 дән Ташлы Елга исеме б-н мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, су тегермәне, ашлык саклау-сату һәм 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 963 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Афанас волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 25 гыйнварыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1970 тә — 507, 1897 дә — 767, 1906 да — 848, 1920 дә — 847, 1926 да — 119, 1949 да — 650, 1958 дә — 701, 1970 тә — 744, 1979 да — 700, 1989 да — 470, 2002 дә — 445 кеше.

**ТАШЛЫЯ́Р**, к. *Яңа Мочалкино*, Мамадыш р-ны.

**ТАШЛЫЯ́Р** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 17 *км* көньяк-көнбатыштарак, Мәллә елгасы буенда. 2010 елда 439 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да мәчет, мәктәп, атлы ярма яргыч, ашлык саклау-сату һәм 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1824,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Кармалы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1816 да — 142 ир-ат, 1834 тә — 361, 1870 тә — 528, 1897 дә — 823, 1906 да — 848, 1920 дә — 986, 1926 да — 757, 1938 дә — 800, 1949 да — 758, 1958 дә — 618, 1970 тә — 730, 1979 да — 620, 1989 да — 479, 2002 дә — 437 кеше.

**ТАШЛЫЯ́Р** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 42 *км* көнчыгыштарак, Нырсы елгасы буенда. 2010 елда 10 кеше (руслар) яши. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек һәм итек тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1049,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әбде волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1859 да — 383, 1897 дә — 552, 1908 дә — 486, 1920 дә — 507, 1926 да — 527, 1970 тә — 100, 1979 да — 60, 1989 да — 17, 2002 дә — 12 кеше.

**ТАШМАҢГАЙЛА́Р** (Hyhophthalmichthynae), карплар семьялыгыннан төче су балыклары ассемьялыгы. 2 ыругы, 2 төре билгеле: ак ташмаңгай (Hypophthalmichthys molitrix) һәм чуар ташмаңгай (Aristichthys nobilis). Көнчыгыш һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия елгаларында таралганнар. Ак ташмаңгайның озынлыгы 1 *м* га, авырлыгы 16 *кг* га җитә. Зәңгәрсу-көмешсыман төстә, йөзгечләре кара. Биек гәүдәле, ян-яктан нык кына кысылган. Авызы өскә караган. Күзләре түбән урнашкан. Корсагында бугазыннан аналь тишемгә кадәр киль сузылган. Саңак төкчәләре еш кына кушылып үсә. Тәңкәсе вак, җиңел коела. Кремнийлы яшел суүсемнәр б-н туклана. Яшәвенең 5–8 нче елында җенси җитлегә, үрчемлелеге — 490–540 мең уылдык бөртеге. Чуар ташмаңгайның озынлыгы 80 *см* га, авырлыгы 12 *кг* га кадәр. Башы зур. Корсагында киль юк. Саңак төкчәләре кушылмаган. Соры төстә, сырты кара: ян-ягына күпсанлы кара нокталар сибелгән. Җылылык яратучы төр. Зоопланктон б-н туклана. Яшәвенең 4–6 нчы елында җенси җитлегә, үрчемлелеге — 1 млн. га кадәр уылдык бөртеге. ТРда «Арча», «Кайбыч», «Үшнә» балык хуҗалыкларында Т.ның читтән китерелгән яшь кушылгак формаларын сатарлык авырлыкка кадәр (3 яшьтә 1–1,2 *кг*) үстерәләр. Ел саен 300–400 *т* балык җитештерелә.

**ТАШНЫ́ УЕ́П БИЗӘ́К ЯСА́У**, махсус корал (кискеч) ярдәмендә ташны сәнгатьле эшкәртү юлы б-н сурәтләр, бизәкләр уеп ясау; тиешле техника б-н башкарылган сәнгать әсәрләре җыелмасы. Татар *бизәлеш сәнгате* төре буларак, Т.у.б.я. монументаль архит-рада һәм кабер ташлары ясауда үсеш ала (к. *Уеп ясалган кабер ташлары*). Известьташ һәм туф киң таралган материал булып санала. Эшкәртүгә җиңел бирешүләре кисеп бизәк ясаучыларга, тирән уемлы һәм яссы рельефлы кисү техникасын кулланып, катлаулы бизәк композицияләре иҗат итәргә мөмкинлек бирә; архит-ра декорында ул фон яссылыгына авыш почмак ясап башкарыла, сизелер-сизелмәс яктылык һәм күләгә алмашы үз чиратында бизәкне ачыграк итә. Ташны уеп ясалган монументаль бизәкләрнең хәзергәчә сакланып калган иң баштагы үрнәкләре Алтын Урда чорына карый: Болгар шәһәрендәге Җамигъ мәчет һәм бер төрбәнең археол. калдыклары, Кече манара бизәлеше. Чәчәк-үсемлек үрнәкләреннән (пальметта, ярымпальметта, лалә, тукранбаш, яфраклы яшь ботак), ш.у. арабеска һәм гирихлар (мөселман орнаменты төрләре) хасил итүче розеткалар, «йөрәкләр», баулар, күппочмаклардан торган, гарәпләрнең «сөлс» һәм «куфи» ысулында бормалы язулары б-н аралаштырылып ясалган бизәкләр ишек һәм тәрәзә уемнары кысаларын, порталларны, куышларны, каймаларны, áркаларны бизәп торганнар. Орнамент аша Кече Азия, Кырым, Әзәрбайҗан архит-ра декорындагы сәлҗүкләр стиле б-н элемтә барлыгы күренә.

Кече архитектур пластикада — 13–15 йөзләрнең 1 нче яртысына караган кабер ташларында — бизәк (башлыча, кояш һәм чәчәк-үсемлек үрнәгендәге розеткалар) кабер ташларының икенче арткы ягына төшерелгән, алгы яссылыкны гарәп шрифтындагы язулар һәм өске өлештәге кайма б-н аерымланган бизәк алып торган (яфраклы яшь ботак үрнәгендә). Кулланылган үрнәкләр Урта һәм Якын Көнчыгыш мөселман сәнгате б-н бәйләнеш булуын исбатлый.

Барысы да диярлек яссы рельефлы кисү техникасында бизәлгән кабер ташлары Казан ханлыгы чорының Т.у.б.я. сәнгате турында сөйли. Аларның алгы, еш кына арткы, ян-як өлешләре дә орнамент б-н чуарланган (аларда Казанның хәзерге көннәргә кадәр сакланмаган таш корылмаларындагы уеп ясалган пластика үрнәкләре чагылыш табуы ихтимал). Гарәп графикасындагы «сөлс» һәм «куфи» ысулы б-н башкарылган язмалар каллиграфиясе дә камилләшә. Орнамент уеп ясалган бизәкнең нәфис формалары һәм төгәл эшләнгән контурлары б-н «җәннәт бакчасы» композициясен күз алдына китерүче чәчәк-үсемлек бизәкләре (дәлия, кашкарый,

алтын гөл, лалә, гөләп, ярымачылган чәчәк бөреләре һ.б.) комплексы хисабына байый. Дулкынсыман розетка-медальоннарга Коръән аятьләреннән алынган хикмәтле нәфис язулар урнаштырыла. Шактый биек рельеф һәм композицияләрнең катлаулылыгы 16 йөз уртасында Т.у.б.я. техникасының иң югары ноктага ирешүен чагылдыра. 18 йөз урталарына кадәр татар кабер ташларындагы бизәлеш ирешелгән дәрәҗәсен кабатлый, ләкин сәнгати сыйфат һәм стильнең купшылыгы акрынлап кимүгә бара. Уеп ясалган бизәкләр мәйданы, уеп кисү тирәнлеге, тышкы өслекнең фонга карата үзенчәлекле кисү тирәнлеге кечерәя, башкарылуы күпкә гадирәк тирән уемлы кисү техникасы ешрак файдаланыла.

19 йөзнең 2 нче яртысыннан уеп ясалган орнамент инде сирәк эпитафияләрдә генә кулланыла, төп урынны истәлек язулары һәм Коръән аятьләре алып тора. Кайвакыт ташларның өске өлешендә шушы чорда *агачка уеп кисүдә* бик тә популяр булган кояш билгесе үрнәкләре очрый.

18 йөзнең 2 нче яртысында монументаль Т.у.б.я. мәчетләр һәм аерым йортлар бизәлешендә кабат тергезелә. Ул яссы рельефлы техникада гадәти башкарыла, кулланылган үрнәкләрдә шул чорның архит-ра стильләрен (барокко, ампир, эклектика һ.б.) чагылдыра; Казан һәм Казан губернасының башка шәһәрләрдәге рус корылмаларына хас монументаль Т.у.б.я.дан аермалы буларак, аны урталык саклау һәм кырыслык аерып тора (к. *Архитектура бизәге*).

Ташны уеп бизәк ясаучылар аерым һөнәр осталары булганнар. Шәһәр һәм авыл остаханәләрендә заказга эшләгәннәр. Т.у.б.я. халык иҗатында үсешкә ирешә алмый. Сәнгать төре буларак, ул, башлыча, архит-ра декоры өлкәсенә күчә һәм бина фасадларын бизәүдә кулланыла.

*Әд.:* Валеев Ф.Х. Орнамент Казанских татар. К., 1969; шул ук. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; шул ук. Татарский народный орнамент. К., 2002; Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф. Древнее искусство Татарстана. К., 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ТАШСУ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сая елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 101 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Айбаш юлындагы авыл исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 775,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Салкын Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 56 ир-ат; 1859 да — 335, 1897 дә — 422, 1908 дә — 454, 1920 дә — 415, 1926 да — 446, 1938 дә — 426, 1949 да — 303, 1958 дә — 235, 1970 тә — 269, 1989 да — 107, 2002 дә — 111 кеше. Т.да җәмәгать һәм сәясәт эшлеклеләре Ә.*Максуди* һәм С.*Максуди* туган.

**«ТАШТА́У»**, ерым-сызалар системасы, Тәтеш р-ны Монастырский авылы янында; ландшафтлы табигать истәлеге. 1981 елда билгеләнә. Мәйданы 32 *га*. Идел елгасының уңъяк ярындагы җир асты су чыгышлары булган, көнбатышка таба авыш тирән ерымнар (20 *м* га кадәр). Пермь системасы Татар ярусының кызыл утырмаларыннан тора. 1950 елда Тәтеш урман хуҗалыгы тарафыннан Себер карагае һ.б. токымнардан торучы 20 *м* киңлектәге һәм 2 *км* озынлыктагы саклаучы урман утырмаларына нигез салына (бу эш б-н Татарстан урман-тәҗрибә станциясе хезмәткәре Г.Г.Мгебров җитәкчелек итә). 10 елдан соң, яр кашларына агач утырткач, ерым зураюдан туктала, ярлары сөзәкләнә. Хәзер Себер карагаеның биеклеге 18 *м* га җитә, ерымның төбендә һәм сөзәклекләрендә имән, карама, чикләвек, сәрви, болын үсемлекләре үсә. Рельефның үзенчәлекләре һәм кыр уртасындагы кеше тарафыннан булдырылган үсемлекләр «утраучыгы» күп кенә хайван төрләренең тереклеге өчен уңай шартлар тудыра. Биредә ТРның Кызыл китабына кертелгән бытбылдык, соры көртлек, кыр карчыгасы, дүдәк очрый. Объект туфрак саклаучы, фәнни һәм мәдәни танып белү әһәмиятенә ия.





«Таштау» ерым-сызалар системасы.
1. Гомуми күренеше; 2. Карагай утыртмалары. 1950.

*Әд.:* Мурзов А.И. Опыт выращивания лиственницы в Татарии // Опыты применения механизмов в лесокультурной практике и выращивания быстрорастущих пород в Татарской АССР. К., 1961; Мурзов А.И., Гильмутдинов К.Г. Зелёная защита полей. К., 1967.

**ТАШТИМЕ́Р (БАШТИМЕ́Р) БӘК** (?–1425), Күк Урда идарәчесе. Кондырча (1391) һәм Терек (1395) елгалары буйларындагы сугышларда Туктамыш хан ягында катнаша. Терек янында Урта Азия идарәчесе Аксак Тимер гаскәрләре тарафыннан җиңелгәннән соң, Дон буена кача; аннары Кырымда хакимиятне кулга төшерә. Акча суга. 1398 дә бәкләр бәге Идегәй тарафыннан Кырымнан куыла. 15 йөз башында Аксак Тимер сараенда хезмәт итә.

*Әд.:* Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

*И.Л.Измайлов.*

**ТАШУ́ КАРА́У** (боз карау), язын елгада боз китү уңае б-н үткәрелә торган традицион татар халык бәйрәме. Гадәттә, татар авылларында яшәүче халык язгы боз китү күренешен күзәтергә чыга. Елгалар боздан арчылганда кышны озату йоласы үтәлә: ул боз өстендә салам ягып агызу, яр буенда яшьләрнең гармун уйнау, җырлау, бию, әйлән-бәйлән уеннары рәвешендә уза. Кайбер очракларда саламнан карачкы ясыйлар, аны соңгы боз кисәкләренең берсенә беркетәләр һәм ут төртеп агызып җибәрәләр, ул яз һәм җылы килүен гәүдәләндерә. Себер татарларында Т.к. вакытында тылсымлы элементлар сакланган, бәйрәмдә катнашучыларга сәламәтлек теләгәннәр, суга махсус әзерләнгән курчаклар, ш.у. иске кием-салым, тәңкәләр ташлаганнар; тәвәккәлрәкләре суга чумып алган. 20 йөздә Т.к. элекке әһәмиятен югалта.

*Әд.:* Уразманова Р.К. Весенне-летний цикл обрядов и праздников // Татары. М., 2001.

**ТАШЧИШМӘ́** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 12 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ашыт елгасы буенда. 2010 елда 366 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — Мамендәлеевка, Тазлар; 19 йөздән Иске Тазлар буларак билгеле; 1941 нең 17 февраленнән хәзерге исемен йөртә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, кирпеч сугу, мич чыгару, он тарту, курыс төшерү һәм агач кайрысыннан әйберләр ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Иске Тазларда мәчет, мәктәп, су тегермәне, тимерче алачыгы, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1332,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Мәңгәр волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 190 ир-ат; 1859 да — 821, 1897 дә — 1150, 1908 дә — 1190, 1920 дә — 1052, 1926 да — 990, 1970 тә — 633, 1979 да — 566, 1989 да — 454, 2002 дә — 377 кеше.

**ТАШЪЕЛГА́**, Көнчыгыш Кама аръягында, Мөшеге елгасының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 10 *км*. Бассейнының мәйданы 38,5 $км^2$. Елга башы Мөслим р-ны Ташъелга авылыннан көньяктарак урман массивында, тамагы — Минзәлә р-ны Әтрәкле авылыннан төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы — 90 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,3 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену

модуле 0,25–0,5 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы, җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 89 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,025 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**ТАШЪЕЛГА́** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 16 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ташъелга елгасы буенда. 2010 елда 115 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, иткә терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1923 тә нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Минзәлә кантоны Мөслим волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1926 да — 400, 1938 дә — 214, 1949 да — 334, 1958 дә — 292, 1970 тә — 238, 1979 да — 193, 1989 да — 156, 2002 дә — 135 кеше.

**ТАЮ́РСКИЙ** Дмитрий Альбертович (23.11.1963, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (2000), проф. (2004). 1985 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, гомуми физика каф. профессоры (2003 тән). Хезмәтләре куертылган тирәлекләрнең үзлекләренә, квант сыеклыкларына, түбән темп-ралар физикасына карый. Т. түбән һәм үтә түбән темп-раларда диэлектрик кристалларның спин системалары кинетикасы һәм термодинамикасы теориясен, көчле магнит кырларындагы диэлектрик кристалларда Ван-Флек парамагнетизмы теориясен төзи. Этилсульфат кристалларында тулий ионнарының югары ешлыклы ЭПР эффектын, $CeRu_2Si_2$ фермион кушылмасында магнит кырына фазалы квант күчешен ачыклый. Сыек гелий-3 һәм диэлектрик Ван-Флек парамагнетиклары арасындагы магнит бәйләнешенең табигатен билгели. Ван-Флек парамагнетиклары физикасына караган хезмәтләр циклы өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2006).

Х е з м.: High-frequency tltctron paramagnetic resonance of $Tm^{3+}$ ions in lanthanum and thulium ethylsulphate single crystals // Physical Review Letters. 1996. V. 77 (автордаш); Insulating Van Vleck Paramagnets at High Magnetic Field // Journ. of Low Temperature Physics. 2002. V. 28 (автордаш); A Nonextensive Approach to Bose-Einstein Condensation of Trapped Interacting Boson Gas // Journ. of Low Temperature Physics. 2008. V. 150 (автордаш).

## ТАССР ҺӘМ ТРдагы АДМИНИСТРАТИВ РАЙОННАР ИСЕМЛЕГЕ

1930 елның 1 октябренә

1. Аксубай
2. Актаныш
3. Акташ
4. Алабуга
5. Алексеев
6. Апас
7. Арча
8. Әгерже*
9. Әлки
10. Әлмәт
11. Балык Бистәсе*
12. Баулы
13. Беренче Май
14. Биләр
15. Бөгелмә
16. Бондюг (1931 дә таркатыла)
17. Буа
18. Дөбъяз
19. Зөя* (1931 дә таркатыла)
20. Казан авыл* (1938 дә таркатыла)
21. Кайбыч*
22. Кама Тамагы
23. Красный Бор
24. Кукмара
25. Лаеш*
26. Мамадыш
27. Минзәлә
28. Мөслим
29. Норлат*
30. Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат)
31. Питрәч
32. Саба
33. Сарман
34. Спас (1935 нең 1 апр. – 1991 нең 4 окт. Куйбышев)
35. Тәкәнеш (1932 дә таркатыла)
36. Тәмте* (1931 дә таркатыла)
37. Тәтеш
38. Түнтәр (1932 нең 2 мартыннан – Балтач)
39. Тукай (үзәге — Яңа Кенәр а., 1938 нең 25 мартыннан – Әтнә)
40. Тымытык (1931 нең 20 октябреннән – Азнакай)
41. Чаллы (1976 ның 20 апреленнән –Тукай)
42. Чистай
43. Чүпрәле
44. Ширәмәт
45. Шөгер (1959 ның 12 октябреннән – Лениногорск)
46. Яңа Чишмә

Искәрмәләр:

* 1927 дә оештырыла
** 1935 тә оештырыла
*** 1938 дә оештырыла
**** 1944 тә оештырыла

1948 елның 1 гыйнварына

1. Азнакай
2. Аксубай
3. Актаныш
4. Акташ (1959 да таркатыла)
5. Алабуга
6. Алексеев
7. Апас
8. Арча
9. Әгерже
10. Әлки
11. Әлмәт
12. Әтнә (1959 елда таркатыла)
13. Балтач
14. Балык Бистәсе
15. Баулы
16. Беренче Май
17. Биектау**
18. Биләр
19. Бөгелмә
20. Бондюг** (1963 тә таркатыла)
21. Буа
22. Будённый**( 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы; 1959 да таркатыла)
23. Ворошилов (1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл; 1959 да таркатыла)
24. Дөбъяз
25. Зәй**
26. Кайбыч
27. Калинин** (1959 да таркатыла)
28. Кама Тамагы
29. Корноухово**** (1944 нең 5 апреленнән — Солтан; 1954 елда таркатыла)
30. Красный Бор (1960 та таркатыла)
31. Кузнечиха** (1960 та таркатыла)
32. Куйбышев
33. Кукмара
34. Кызыл Армия** (1958 дә таркатыла)
35. Кызыл Йолдыз** (1959 да таркатыла)
36. Кызыл Юл** (үзәге — Яңа Кенәр а., 1956 ның 18 июленнән — Тукай)
37. Лаеш
38. Мамадыш
39. Матвеевка**** (1954 тә таркатыла)
40. Минзәлә
41. Мөслим
42. Морт**** (1944 нең 8 июненнән — Костенеево; 1954 елда таркатыла)
43. Нурлат
44. Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат)
45. Олы Тархан *** (1959 да таркатыла)
46. Питрәч
47. Подберезье**** (1956 да таркатыла)
48. Саба
49. Сарман
50. Столбище*** (1959 да таркатыла)
51. Тәкәнеш** (1960 та таркатыла)
52. Тәмте** (1958 дә таркатыла)
53. Тәтеш
54. Теләче** (1959 да таркатыла)
55. Тельман** (1958 дә таркатыла)
56. Тымытык** (1958 дә таркатыла)
57. Чаллы (үзәге — Чаллы ш., 1976 ның 20 апреленнән — Тукай)
58. Чепья*** (1958 дә таркатыла)
59. Чистай
60. Чүпрәле
61. Чүриле**** (1956 да таркатыла)
62. Ширәмәт
63. Шөгер (1959 ның 12 октябреннән — Лениногорск)
64. Югары Ослан (1931 дә оештырыла)
65. Юдино*** (1958 нең 16 июленнән — Яшел Үзән)
66. Ютазы**
67. Юхмачы**** (1956 да таркатыла)
68. Ямаш**** (1956 да таркатыла)
69. Яңа Писмән** (1955 нең 18 августыннан — Лениногорск)
70. Яңа Чишмә

*ТАССР һәм ТРдагы административ районнар исемлеге (дәвамы)*

1963 елның 1 сентябренә

**Авыл районнары:**

1. Алабуга
2. Арча
3. Әлмәт
4. Бөгелмә
5. Буа
6. Куйбышев
7. Лениногорск
8. Мамадыш
9. Минзәлә
10. Октябрь
11. Питрәч
12. Саба
13. Сарман
14. Тәтеш
15. Чаллы
16. Чистай
17. Яшел Үзән

**Сәнәгать районы:**

18. Азнакай (1965 тә таркатыла)

1966 елның 1 гыйнварына

1. Азнакай**
2. Аксубай**
3. Актаныш**
4. Алабуга
5. Алексеев*
6. Апас*
7. Арча
8. Әгерҗе*
9. Әлки**
10. Әлмәт
11. Балтач**
12. Балык Бистәсе**
13. Баулы**
14. Биектау**
15. Бөгелмә
16. Буа
17. Кама Тамагы**
18. Куйбышев
19. Кукмара**
20. Лаеш**
21. Лениногорск
22. Мамадыш
23. Минзәлә
24. Мөслим**
25. Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат)
26. Питрәч
27. Саба
28. Сарман
29. Тәтеш
30. Түбән Кама**
31. Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай)
32. Чирмешән**
33. Чистай
34. Югары Ослан**
35. Яшел Үзән

Искәрмәләр:
* 1964 тә оештырыла
** 1965 тә оештырыла

2010 елның 1 гыйнварына

1. Азнакай
2. Аксубай
3. Актаныш
4. Алабуга
5. Алексеев
6. Апас
7. Арча
8. Әгерҗе
9. Әлки
10. Әлмәт
11. Әтнә
12. Балтач
13. Балык Бистәсе
14. Баулы
15. Биектау
16. Бөгелмә
17. Буа
18. Зәй
19. Кайбыч
20. Кама Тамагы
21. Кукмара
22. Лаеш
23. Лениногорск
24. Мамадыш
25. Менделеев
26. Минзәлә
27. Мөслим
28. Нурлат
29. Питрәч
30. Саба
31. Сарман
32. Спас
33. Тәтеш
34. Теләче
35. Түбән Кама
36. Тукай
37. Чирмешән
38. Чистай
39. Чүпрәле
40. Югары Ослан
41. Ютазы
42. Яңа Чишмә
43. Яшел Үзән

*1 нче таблица*

1940–90 елларда Татарстанда совхозлар үсешенең төп күрсәткечләре*

| Күрсәткечләр | Еллар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1940 | 1960 | 1970 | 1980 | 1985 | 1990 |
| Совхозлар саны | 56 | 53 | 167 | 250 | 278 | 335 |
| А.х. җирләренең мәйданы, барлыгы (мең *га*), | 227,3 | 913,2 | 1212,5 | 1459,4 | 1440,5 | 1436,1 |
| ш.и. чәчүлек мәйданы (мең *га*) | 142,7 | 764,9 | 910,7 | 1096,5 | 1029,7 | 1064,4 |
| Мөгезле эре терлек (мең баш), | 25,5 | 152,8 | 268,9 | 426,6 | 455,4 | 433,0 |
| ш.и. сыерлар | 10,9 | 51,3 | 82,1 | 133,2 | 132,1 | 128,8 |
| Төп продуктларны җитештерү: | | | | | | |
| бөртекле ашлык (мең *т*) | 71,7 | 506,2 | 822,3 | 945,7 | 1132,1 | 1174,0 |
| ит (сугым авырлыгы, мең *т*) | 1,5 | 18,2 | 29,0 | 58,7 | 72,9 | 93,7 |
| сөт (мең *т*) | 19,0 | 124,4 | 230,0 | 300,0 | 332,4 | 411,7 |
| йомырка (млн. данә) | 4,3 | 27,6 | 126,3 | 535,7 | 734,7 | 798,6 |
| йон (*т*) | 47,0 | 361,0 | 390,0 | 415,0 | 499,0 | 455,0 |
| Тракторлар (данә) | 932 | 2811 | 6863 | 10646 | 10841 | 11041 |
| Ашлык комбайннары (данә) | 266 | 2019 | 2551 | 4027 | 6533 | 4558 |
| Йөк автомобильләре (данә) | 234 | 1657 | 3028 | 4635 | 5457 | — |

* *Совхоз* мәкаләсенә.

## ТАТАРЛАР САНЫ ҺӘМ АЛАРНЫҢ ТАРАЛЫП УРНАШУЫ

*2 нче таблица*

**1719–2002 елларда Россиядә, СССР һәм дөньяда татарлар саны үсеше, кеше саны (меңнәрдә)**

| 18 йөз | 19 йөз | 20 йөз – 21 йөз башы |
|---|---|---|
| 1719 – 290* | 1833 – 1327,7 | 1912 – 3253,9 |
| 1744 – 495–500** | 1857 – 1705,4 | 1926 – 3369,4**** |
| 1762 – 435* | 1897 – 2552,0 | 1939 – 4314,0 |
| 1782 – 672,7*** | | 1959 – 4967,7 |
| 1795 – 835,1 | | 1970 – 5930,7 |
| | | 1979 – 6317,5 |
| | | 1989 – 6920,5**** |
| | | 2002 – 7920,5***** |

Искәрмәләр:
1. Мәгълүматлар юк:
   * Кырым һәм Польша-Литва татарлары саны буенча
   ** Себер татарлары саны буенча
   *** Польша-Литва татарлары саны буенча
2. **** ш.и. 1926 елда — 179,1 мең, 1989 елда 271,7 мең Кырым татары
3. ***** дөньяда татарларның гомуми саны

*3 нче таблица*

**18 йөздә – 20 йөз башында татарларның төп этнотерриториаль төркемнәре саны үсеше**

| Татарларның этнотерриториаль төркемнәре | Төрле елларда татарлар саны (кеше саны меңнәрдә), шәһәр халкы % | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1719 | 1744 | 1762 | 1782 | 1795 | 1833 | 1857 | 1897 | 1912 |
| Идел-Урал буе татарлары | 261,1 | 327,1 | 396,8 | 509,3 | 617,3 | 1019,5 | 1416,1 | 2249,5 | 2936,0 |
| шәһәр халкы % | 0,7 | 1,6 | 1,7 | 1,7 | 1,8 | 2,3 | 2,0 | 4,9 | 4,9 |
| Себер татарлары | 23,0 | – | 29,0 | 32,3 | 35,0 | 41,8 | 45,2 | 69,4 | 75,6 |
| шәһәр халкы % | – | – | 1,2 | 1,4 | – | 1,1 | 2,2 | 4,5 | 4,7 |
| Әстерхан татарлары | 6–8 | 5,4 | 9,2 | 10,9 | 13,0 | 22,9 | 25,7 | 38,8 | 48,4 |
| шәһәр халкы % | 19–25 | 37,0 | 21,7 | 16,5 | 25,4 | 21,4 | 19,5 | 39,7 | 37,8 |
| Польша–Литва татарлары | – | 3,0 | – | – | 3,3 | 6,0 | 7,3 | 8,9 | 12,5 |

*4 нче таблица*

**18–19 йөзләрдә Идел-Урал төбәгендә татарлар саны һәм аларның таралып урнашуы, кеше саны**

| Губерналар, өязләр | Еллар 1762 | 1782 | 1795 | 1833 | 1857 | 1897 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Вятка губернасы** | 21772 | 27959 | 32561 | 60102 | 89630 | 147200 |
| Глазов өязе | 924 | 1343 | 1698 | 3805 | 4621 | 7884 |
| Алабуга өязе | 5345 | 7437 | 9132 | 19144 | 28411 | 52239 |
| Малмыж өязе | 12628 | 15349 | 17724 | 27166 | 41897 | 52228 |
| Сарапул өязе | 504 | 836 | 1017 | 3053 | 4963 | 15884 |
| Слободской өязе | 1434 | 1771 | 1998 | 2676 | 3267 | 4277 |
| Уржум өязе | 937 | 1223 | 1002 | 4258 | 6471 | 13934 |
| Башка өязләр | – | – | – | – | – | 754 |
| **Казан губернасы** | 155444 | 191854 | 214671 | 363094 | 455278 | 675419 |
| Казан өязе | 46220 | 56046 | 61340 | 87160 | 99946 | 146730 |
| Лаеш өязе | 13118 | 15776 | 19774 | 43527 | 49367 | 73045 |
| Мамадыш өязе | 26350 | 31416 | 36010 | 65464 | 92581 | 131732 |
| Зөя өязе | 9998 | 11916 | 12100 | 19423 | 23635 | 37802 |
| Спас өязе | 11822 | 14682 | 15554 | 25928 | 35316 | 52952 |
| Тәтеш өязе | 23480 | 29230 | 30554 | 50956 | 56130 | 91214 |
| Царёвококшайск өязе | 4956 | 6962 | 8114 | 18661 | 20924 | 23789 |
| Цивильск өязе | 2808 | 3792 | 4870 | 6306 | 10808 | 16368 |
| Чабаксар өязе | 884 | 986 | 1102 | 1636 | 2085 | 3397 |
| Чистай өязе | 15848 | 20998 | 25253 | 46498 | 61468 | 98304 |
| Башка өязләр | – | – | – | 35 | 18 | 72 |
| **Түбән Новгород губернасы** | 10783 | 14577 | 15884 | 20411 | 33711 | 41337 |
| Васильсурск өязе | 2252 | 2867 | 3385 | 5188 | 8982 | 10889 |
| Княгинин өязе | 603 | 1055 | 790 | 1280 | 1707 | 1992 |
| Сергач өязе | 7928 | 10655 | 11583 | 16320 | 22849 | 27196 |
| Башка өязләр | – | – | 118 | 183 | 207 | 1260 |
| **Оренбург губернасы** | 12229 | 18491 | 23995 | 42632 | 79388 | 126225 |
| Верхнеуральск өязе | 1757 | 2376 | 3583 | 7959 | 16724 | 23865 |
| Оренбург өязе | 8694 | 13822 | 14603 | 25727 | 46927 | 71158 |
| Троицк өязе | 646 | 832 | 2331 | 3163 | 7844 | 17286 |
| Чиләбе өязе | 1132 | 1461 | 3478 | 5789 | 9910 | 13910 |
| **Пенза губернасы** | 20336 | 25389 | 24986 | 34912 | 45321 | 58530 |
| Городище өязе | 322 | 406 | 448 | 1028 | 1641 | 2843 |
| Инсар өязе | 4086 | 6333 | 5716 | 8532 | 11368 | 13075 |
| Керенск өязе | 1576 | 2080 | 2168 | 2731 | 3292 | 4915 |
| Краснослободск өязе | 6116 | 6867 | 5969 | 8304 | 11127 | 14321 |
| Мокшан өязе | 354 | 385 | 422 | 761 | 1069 | 1731 |
| Түбән Ломов өязе | 732 | 826 | 480 | 519 | 829 | 1077 |
| Саранск өязе | 3650 | 4037 | 4454 | 5525 | 7442 | 11269 |
| Чембар өязе | 3500 | 4395 | 5329 | 7510 | 8553 | 8345 |
| Башка өязләр | – | – | – | – | – | 37 |
| **Пермь губернасы** | 8984 | 11987 | 17524 | 27274 | 41442 | 81236 |
| Екатеринбург өязе | 209 | 269 | 448 | 882 | 2220 | 4277 |
| Красноуфимск өязе | 1999 | 3317 | 5233 | 9715 | 16400 | 26046 |
| Көнгер өязе | 1280 | 1640 | 2182 | 1506 | 1956 | 2722 |

| Губерналар, өязләр | Еллар 1762 | 1782 | 1795 | 1833 | 1857 | 1897 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Оса өязе | 2599 | 3345 | 4213 | 6896 | 7801 | 16364 |
| Пермь өязе | 305 | 313 | 418 | 1274 | 2360 | 7054 |
| Шадрин өязе | 2592 | 3103 | 5130 | 7000 | 10685 | 17739 |
| Башка өязләр | – | – | – | – | – | 6978 |
| **Рязань губернасы** | 4265 | 4807 | 5999 | 5591 | 5656 | 5033 |
| Касыйм өязе | 4265 | 4807 | 5999 | 5591 | 5647 | 4764 |
| Башка өязләр | – | – | – | – | 12 | 146 |
| **Самара губернасы** | 21717 | 30314 | 47245 | 85444 | 131554 | 259820 |
| Бөгелмә өязе | 13082 | 18738 | 27193 | 40938 | 61674 | 137885 |
| Богырыслан өязе | 3971 | 5409 | 8405 | 14246 | 25093 | 41580 |
| Бозаулык өязе | – | – | 1806 | 2902 | 6239 | 11404 |
| Яңа Үзән өязе | – | – | – | 2636 | 6632 | 13008 |
| Николаев өязе | – | – | – | 1400 | 2176 | 3515 |
| Самара өязе | 602 | 1042 | 2765 | 4748 | 5536 | 14000 |
| Ставрополь өязе | 4062 | 5125 | 7066 | 18249 | 24204 | 38396 |
| **Саратов губернасы** | 18538 | 25798 | 31218 | 47040 | 57628 | 94693 |
| Вольск өязе | 422 | 652 | 948 | 1511 | 1926 | 3173 |
| Кузнецк өязе | 9644 | 11682 | 13491 | 18478 | 20315 | 35344 |
| Петровск өязе | 1752 | 3598 | 4630 | 6564 | 8840 | 12394 |
| Саратов өязе | 184 | 398 | 554 | 119 | 274 | 1925 |
| Хвалын өязе | 6536 | 9468 | 11301 | 20368 | 26382 | 39536 |
| Башка өязләр | – | – | 294 | – | – | 2321 |
| **Сембер губернасы** | 34400 | 39053 | 46419 | 67654 | 90069 | 133977 |
| Ардатов өязе | 722 | 582 | 730 | 964 | 1000 | 1659 |
| Буа өязе | 16272 | 20435 | 22867 | 33050 | 43741 | 63046 |
| Карсун өязе | 1760 | 1749 | 2353 | 3941 | 5009 | 8387 |
| Кормыш өязе | 6848 | 8246 | 11699 | 15608 | 19001 | 24260 |
| Сенгилей өязе | 1072 | 941 | 1596 | 2935 | 5000 | 6894 |
| Сембер өязе | 6738 | 5736 | 5778 | 8339 | 12239 | 22133 |
| Сызрань өязе | 988 | 1363 | 1396 | 2817 | 4032 | 7491 |
| Башка өязләр | – | – | – | – | – | 107 |
| **Тамбов губернасы** | 5616 | 6393 | 7484 | 10740 | 13152 | 16976 |
| Елатьма өязе | 351 | 404 | 2557 | 4034 | 4157 | 5919 |
| Спас өязе | 816 | 858 | 875 | 1053 | 1355 | 2201 |
| Тамбов өязе | 260 | 234 | 395 | 681 | 806 | 1176 |
| Темников өязе | 3930 | 4612 | 3278 | 4394 | 5753 | 5901 |
| Шацк өязе | 259 | 285 | 379 | 578 | 867 | 1026 |
| Башка өязләр | – | – | – | – | – | – |
| **Уфа губернасы** | 82686 | 112721 | 140211 | 254620 | 373219 | 609091 |
| Бәләбәй өязе | 16625 | 27232 | 34288 | 70269 | 84337 | 173507 |
| Бөре өязе | 15278 | 18699 | 25520 | 42515 | 76142 | 127512 |
| Минзәлә өязе | 32320 | 40268 | 43121 | 74348 | 98348 | 154503 |
| Эстәрлетамак өязе | 6542 | 9557 | 12683 | 25780 | 47581 | 68187 |
| Уфа өязе | 11881 | 16965 | 24599 | 41708 | 57811 | 85835 |

*5 нче таблица*

**Россия Федерациясендә татарларның таралып урнашуы (1939–2010 еллардагы халык санын алу мәгълүматларына таянып), кеше саны**

| Милли республикалар, өлкәләр һәм башка территориаль берәмлекләр | Еллар | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1939 | 1959 | 1970 | 1979 | 1989 | 2002 | 2010 |
| **Төньяк-Көнбатыш төбәк** | | | | | | | |
| Карелия Респ-касы | – | 4692 | 2603 | 2611 | 2992 | 2629 | 1889 |
| Ненец авт. округы | – | – | 167 | 284 | 524 | 211 | 209 |
| Архангельск өлкәсе | 4845 | – | 4613 | 4906 | 5391 | 3076 | 2335 |
| Вологда өлкәсе | 346 | – | 1028 | 1582 | 1843 | 1859 | 1520 |
| Калининград өлкәсе | – | – | 2752 | 3226 | 3556 | 4734 | 4539 |
| Ленинград өлкәсе | – | 4330 | 5376 | 6255 | 7757 | 9447 | 8695 |
| Мурманск өлкәсе | 4446 | 5566 | 7521 | 9532 | 11459 | 7954 | 5630 |
| Новгород өлкәсе | – | – | 804 | 1355 | 1963 | 2083 | 1661 |
| Псков өлкәсе | – | – | 465 | 705 | 1010 | 1502 | 1233 |
| Ленинград, С.-Петербург | 31506 | 27178 | 32861 | 39416 | 43997 | 35616 | 30881 |
| **Үзәк һәм Үзәк Кара туфраклы төбәк** | | | | | | | |
| Белгород өлкәсе | – | – | 575 | 1217 | 1539 | 3397 | 3238 |
| Брянск өлкәсе | – | – | – | – | – | 1179 | 592 |
| Владимир өлкәсе | – | 8268 | 8447 | 9202 | 9214 | 8678 | 7335 |
| Воронеж өлкәсе | – | – | 1193 | 1428 | 1860 | 3501 | 3340 |
| Иваново өлкәсе | 14761 | 9851 | 10511 | 11061 | 9910 | 8208 | 6696 |
| Калуга өлкәсе | – | – | 1290 | 1814 | 2963 | 4306 | 4208 |
| Кострома өлкәсе | – | – | 3355 | 3054 | 2965 | 2732 | 2225 |
| Курск өлкәсе | – | – | – | – | – | 1581 | 1279 |
| Липецк өлкәсе | – | – | 715 | 749 | 1000 | 1751 | 1974 |
| Мәскәү өлкәсе | 53469 | 52520 | 49193 | 52141 | 51059 | 52892 | 56239 |
| Орёл өлкәсе | – | – | – | – | – | 1424 | 1239 |
| Рязань өлкәсе | 8926 | – | 4057 | 4334 | 4922 | 5575 | 4942 |
| Смоленск өлкәсе | – | – | 571 | 1105 | 2163 | 2429 | 2243 |
| Тамбов өлкәсе | 31553 | – | 2141 | 2193 | 2298 | 2732 | 2292 |
| Тверь (Калинин) өлкәсе | – | – | 4712 | 5196 | 6256 | 6719 | 5862 |
| Тула өлкәсе | 10636 | 15431 | 11500 | 10306 | 9551 | 8974 | 7880 |
| Ярославль өлкәсе | 13558 | 7166 | 7211 | 7400 | 7162 | 6175 | 4983 |
| Мәскәү | 57687 | 80489 | 109293 | 132388 | 157376 | 166189 | 149103 |
| **Төньяк Кавказ төбәге** | | | | | | | |
| Кабарда-Балкар Респ-касы | – | – | 2664 | 3169 | 3005 | 2852 | 2377 |
| Карачай-Чиркәс Респ-касы | – | – | 1668 | 1890 | 2496 | 2022 | 1697 |
| Адыгея Респ-касы | – | 1886 | 2154 | 2420 | 2666 | 2904 | 2571 |
| Дагстан Респ-касы | – | 6013 | 5770 | 5627 | 5579 | 4669 | 3734 |
| Калмык Респ-касы | 2490 | 1044 | 1230 | 1331 | 1312 | 1086 | 1016 |
| Төньяк Осетия-Алания Респ-касы | – | – | 1658 | 1903 | 1968 | 2113 | 1411 |
| Чечен-Ингуш Респ-касы: | 3910 | 5225 | 5571 | 5484 | 5102 | – | – |
| 1. Ингуш Респ-касы | | | | | | 151 | 64 |
| 2. Чечен Респ-касы | | | | | | 2137 | 1467 |
| Краснодар крае | 10475 | – | 17709 | 26072 | 34430** | 25615 | 24847 |
| Ставрополь крае | – | – | 9405 | 10610 | 12951 | 12909 | 11797 |
| Ростов өлкәсе | 8926 | 13857 | 16106 | 16948 | 17132 | 17892 | 13956 |
| **Идел-Урал төбәге** | | | | | | | |
| Башкортстан Респ-касы | 617188 | 768566 | 944507 | 940446 | 1120702 | 995253 | 1013191 |
| Идел буе немецлары АССР | 2638 | – | – | – | – | – | – |
| Коми Респ-касы | – | 8459 | 11908 | 17837 | 25980 | 15690 | 10782 |
| Мари Респ-касы | 27149 | 38821 | 40280 | 40917 | 43747 | 43464 | 38372 |
| Мордва Респ-касы | 47386 | 38636 | 44955 | 45765 | 47328 | 46261 | 43392 |
| Татарстан Респ-касы | 1421514 | 1345195 | 1536431 | 1641607 | 1765404 | 2018893 | 2043085 |
| Удмурт Респ-касы | 40561 | 71930 | 87151 | 99141 | 110347 | 109868 | 99314 |
| Чуаш Респ-касы | 2907 | 31357 | 36217 | 37573 | 35689 | 36399 | 34224 |
| Коми-Пермяк авт. өлкәсе | – | 5623 | 3432 | 1910 | 1454 | 1100 | – |
| Әстерхан өлкәсе | – | 57230 | 67062 | 70781 | 71655 | 77142 | 60524 |
| Волгоград өлкәсе | 64223 | 17744 | 23518 | 25531 | 25973 | 28848 | 24561 |
| Киров өлкәсе | 31401 | 41211 | 45309 | 44900 | 45666 | 43637 | 36541 |
| Курган өлкәсе | – | 19567 | 23932 | 23507 | 22567 | 21986 | 17019 |
| Түбән Новгород өлкәсе | 88241 | 66996 | 71798 | 68637 | 58603 | 50616 | 44115 |
| Оренбург өлкәсе | 104843 | 120944 | 145376 | 151384 | 158564 | 165989 | 151525 |
| Пермь өлкәсе | 80727 | 165829 | 169372 | 157726 | 150460 | 135534 | 115565 |
| Пенза өлкәсе | 64660 | 62233 | 74838 | 78236 | 81307 | 86806 | 86433 |
| Самара өлкәсе | 130471 | 74226 | 93687 | 103605 | 115280 | 127984 | 126152 |
| Саратов өлкәсе | 21329 | 34075 | 43238 | 47948 | 52867 | 57583 | 52888 |
| Свердловск өлкәсе | 80983 | 158222 | 176029 | 179347 | 183781 | 168224 | 143825 |
| Ульянов өлкәсе | – | 96918 | 122409 | 134767 | 159093 | 168773 | 149895 |
| Чиләбе өлкәсе | 119527 | 190227 | 216809 | 219744 | 224605 | 214220 | 180998 |

*5 нче таблица (дәвамы)*

| Милли республикалар, өлкәләр һәм башка территориаль берәмлекләр | Еллар | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1939 | 1959 | 1970 | 1979 | 1989 | 2002 | 2010 |
| **Себер төбәге,** ш.и.: | | | | | | | |
| а) **Көнбатыш Себер** | – | – | – | 334 | 388 | 462 | 414 |
| Ханты-Манси авт. округы | – | 2938 | 14046 | 36899 | 97689 | 107954 | 109018 |
| Ямал-Ненец авт. округы | – | 3952 | 4653 | 8556 | 26431 | 27795 | 28532 |
| Алтай крае | 7388 | – | 8052 | 7864 | 8078 | 8904 | 6795 |
| Кемерово өлкәсе | – | 67382 | 69313 | 64821 | 63116 | 51065 | 40251 |
| Новосибирск өлкәсе | 62212 | 24926 | 28825 | 28549 | 29428 | 27886 | 24160 |
| Омск өлкәсе | 91876 | 36421 | 44330 | 46714 | 49784 | 48116 | 41928 |
| Томск өлкәсе | – | 13449 | 15226 | 17630 | 20812 | 20151 | 17037 |
| Төмән өлкәсе | – | 72306 | 102861 | 136757 | 103306 | 116055 | 246748 |
| б) **Көнчыгыш Себер** | | | | | | | |
| Бурят Респ-касы | 6098 | 8058 | 9991 | 10291 | 10496 | 8196 | 6814 |
| Тува Респ-касы | – | – | 822 | 988 | 1071 | 588 | 353 |
| Саха-Якутия Респ-касы | 4420 | 5172 | 7679 | 10980 | 17415 | 10817 | 8125 |
| Таймыр (Долган-Ненец) авт. округы | – | – | 429 | 522 | 783 | 427 | – |
| Усть-Урда Бурят авт. округы | – | 4213 | 5692 | 4782 | 4374 | 4102 | – |
| Чита өлкәсе (ш.и. Агинск-Бурят авт. округы) | 19133 | 4014 | 14283 | 13372 | – | 8159 | – |
| Эвенкия авт. округы | – | – | – | 141 | 330 | 162 | – |
| Красноярск крае | 31266 | 39945 | 46623 | 49894 | 54052 | 43872 | 34925 |
| Иркутск өлкәсе | 30046 | 39061 | 41500 | 41474 | 36609 | 26987 | 22891 |
| в) **Ерак Көнчыгыш** | | | | | | | |
| Еврей авт. өлкәсе | – | – | 1158 | 1460 | 1499 | 1196 | 879 |
| Коряк авт. округы | – | 298 | 353 | 441 | 471 | 216 | – |
| Чукотка авт. округы | – | 504 | 1607 | 1995 | 2270 | 535 | 451 |
| Приморье крае | 11016 | 17004 | 18256 | 19464 | 20211 | 14572 | 10646 |
| Хабаровск крае | 16012 | 14130 | 14571 | 16591 | 17591 | 10982 | 7840 |
| Амур өлкәсе | – | – | 5369 | 7948 | 9095 | 4889 | 3406 |
| Камчатка өлкәсе | – | 2921 | 3728 | 4652 | 5837 | 3404 | 2376 |
| Магадан өлкәсе | – | 3021 | 5295 | 6793 | 8024 | 2002 | 1415 |
| Сахалин өлкәсе | – | 11679 | 11153 | 11030 | 10699 | 6832 | 4883 |

* Кырым татарларын да кертеп

** 1989 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча, Краснодар краендагы татарларның 17217 се — Кырым татарлары

*6 нчы таблица*

**СССРның союздаш республикаларында яшәүче татарлар (1926–1989 еллардагы халык санын алу мәгълүматларына таянып), кеше саны**

| Союздаш республикалар | Еллар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1926 | 1937 | 1959 | 1970 | 1979 | 1989 |
| РСФСР | 3214043 | 3610718 | 4074669 | 475913 | 5016087 | 5543371 |
| Әзәрбайҗан ССР | 9948 | – | 29552 | 31787 | 31350 | 28564 |
| Әрмәнстан ССР | 27 | – | 577 | 581 | 753 | 506 |
| Белоруссия ССР | 3777 | 3475 | 8654 | 10031 | 10911 | 12552 |
| Грузия ССР | 599 | – | 5441 | 5856 | 5165 | 4714 |
| Казакъстан ССР | 79758 | 92096 | 191925 | 287712 | 313460 | 331151 |
| Кыргызстан ССР | 4902 | 17483 | 56266 | 69373 | 72018 | 72992 |
| Латвия ССР | – | – | 1836 | 2688 | 3772 | 4888 |
| Литва ССР | – | – | 3023 | 3460 | 4006 | 5188 |
| Молдавия ССР | – | – | 1047 | 1859 | 2637 | 3477 |
| Таҗикстан ССР | 982 | 16604 | 56893 | 70803 | 79529 | 79442 |
| Төрекмәнстан ССР | 4790 | – | 29946 | 36457 | 40321 | 39277 |
| Үзбәкстан ССР | 28297 | – | 444810 | 573733 | 648764 | 656601 |
| Украина ССР | 22281 | 24242 | 61527 | 76212 | 90542 | 133596 |
| Эстония ССР | – | – | 1535 | 2205 | 3195 | 4070 |

*1 нче кушымта*

СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЙЛАРЫ

| Фамилиясе, исеме, әтисе исеме | Бирелү елы |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Абдерәшитов Шамил Монасыйп улы | 1944 |
| 2. Абдершин Алимкәй Абдулла улы | 1944 |
| 3. Абдершин Рамил Хәйрулла улы | 1944 |
| 4. Абдрахманов Асаф Котдус улы | 1944 |
| 5. Абдуллин Әнвәр Абдулла улы | 1945 |
| 6. Абдуллин Мансур Һидият улы | 1943 |
| 7. Абзалов Рем Абзал улы | 1945 |
| 8. Абрамов Шетиель Семенович | 1945 |
| 9. Абызов Григорий Александрович | 1943 |
| 10. Аипов Мәхмүт Ильяс улы | 1945 |
| 11. Айткулов Сәлим Нигъмәт улы | 1943 |
| 12. Акжегетов Азиз Харьяс улы | 1943 |
| 13. Актуганов Мәхмүт Сафа улы | 1944 |
| 14. Алимов Зариф Закир улы | 1945 |
| 15. Алтынов Николай Николаевич | 1945 |
| 16. Альбетков Вениамин Вәли улы | 1943 |
| 17. Аржанов Николай Николаевич | 1957 |
| 18. Арсланов Гафиятулла Шаһимәрдән улы | 1940 |
| 19. Аскин Гайфетдин Гафиятулла улы | 1945 |
| 20. Афанасьев Александр Петрович | 1945 |
| 21. Афанасьев Кузьма Кириллович | 1945 |
| 22. Ахманов Алексей Осипович | 1945 |
| 23. Аширбәков Әхмәтрәшит Рәшит улы | 1943 |
| 24. Әбдерәзәков Али Касыйм улы | 1944 |
| 25. Әбелханов Садыйк Фәхретдин улы | 1944 |
| 26. Әбләзов Фәхретдин Рәхмәтгали улы | 1945 |
| 27. Әгълетдинов Фәйзулла Хаҗи улы | 1943 |
| 28. Әһлиуллин Хәмит Шәмсетдин улы | 1943 |
| 29. Әсфәндияров Закир Лотфирахман улы | 1944 |
| 30. Әхмәдуллин Мотыйк Әхмәтҗан улы | 1945 |
| 31. Әхмәлдинов Фазылҗан Фазлый улы | 1945 |
| 32. Әхмәров Касыйм Шабан улы | 1943 |
| 33. Әхмәтҗанов Зәйнетдин Низаметдин улы | 1944 |
| 34. Әхмәтшин Ягъфәр Әхмәт улы | 1945 |
| 35. Әхтәмов Сабир Әхтәм улы | 1945 |
| 36. Әхтәмов Хәсән Бәдыйг улы | 1945 |
| 37. Багданов Хәмзә Сәлим улы | 1945 |
| 38. Байморзин Гаяз Исламетдин улы | 1944 |
| 39. Баляев Асым Айзатулла улы | 1944 |
| 40. Баһаветдинов Гыйльми Әбләз улы | 1945 |
| 41. Баталов Фёдор Алексеевич | 1941 |
| 42. Батыршин Гыйльфан Әбубәкер улы | 1938 |
| 43. Башкиров Иван Сергеевич | 1945 |
| 44. Бәдретдинов Миңнулла Бәдретдин улы | 1944 |
| 45. Белоусов Василий Игнатьевич | 1944 |
| 46. Бендиков Степан Михайлович | 1945 |
| 47. Беркутов Александр Максимович | 1944 |
| 48. Болодурин Иван Петрович | 1944 |
| 49. Бочаров Сергей Иванович | 1945 |
| 50. Бөркетов Ибраһим Билал улы | 1943 |
| 51. Булатов Васил Галләм улы | 1944 |
| 52. Бурмистров Вилен Иванович | 1943 |
| 53. Васильев Борис Михайлович | 1941 |
| 54. Васильченко Александр Григорьевич | 1957 |
| 55. Вәзетдинов Гыймазетдин Вәзетдин улы | 1940 |
| 56. Вәлиев Абдулла Хәбибулла улы | 1943 |
| 57. Вәлиев Әгъзам Җиһанша улы | 1946 |
| 58. Вәлиев Әкрам Искәндәр улы | 1945 |
| 59. Вәлиев Леонид Геонаевич (Габделәхәт Габделгани улы) | 1944 |
| 60. Вәлиев Салих Шәйбәк улы | 1943 |
| 61. Винокуров Борис Алексеевич | 1940 |
| 62. Волостнов Николай Дмитриевич | 1945 |
| 63. Воробьёв Пётр Егорович | 1945 |
| 64. Габбасов Габделәхәт Гомәр улы | 1981 |
| 65. Габдрахманов Бари Габдрахман улы | 1944 |
| 66. Габдрәшитов Фәйзулла Габдулла улы | 1944 |
| 67. Гаврилов Аким Андреевич | 1944 |
| 68. Гаврилов Пётр Михайлович | 1957 |
| 69. Гаделшин Хәмит Габдулла улы | 1944 |
| 70. Газизуллин Ибраһим Галим улы | 1944 |
| 71. Гайнетдинов Вячеслав Кәрибулла улы | 1980 |
| 72. Гайнетдинов Махметин (Дмитрий) Галентин улы | 1943 |
| 73. Гайсин Әхмәтсафа Гайсә улы | 1944 |
| 74. Галиев Нургали Мөхәммәтгали улы | 1943 |
| 75. Галиев Фәхразый Гали улы | 1944 |
| 76. Галимҗанов Сәлимҗан Галимҗан улы | 1943 |
| 77. Галимов Вахит Газиз улы | 1944 |
| 78. Гарифуллин Габдулла Гарифулла улы | 1946 |
| 79. Гарнизов Михаил Тихонович | 1944 |
| 80. Гатауллин Әнвәр Җиһангир улы | 1945 |
| 81. Гафиятуллин Газинур Гафиятулла улы | 1944 |
| 82. Гобәйдулин Геннадий Гобәйдулла улы | 1942 |
| 83. Говоров Леонид Александрович | 1945 |
| 84. Гонтарь Константин Михайлович | 1944 |
| 85. Горбанёв Николай Кузьмич | 1944 |
| 86. Горбунов Дмитрий Иванович | 1945 |
| 87. Гордов Василий Николаевич | 1945 |
| 88. Графов Владимир Сергеевич | 1945 |
| 89. Григорьев Виктор Антонович | 1942 |
| 90. Гурьянов Павел Яковлевич | 1943 |
| 91. Гыйззәтов Ширвән Әдият улы | 1945 |
| 92. Гыйззәтуллин Абдулла Гыйбадулла улы | 1944 |
| 93. Гыйззәтуллин Миңнулла Сөнгать улы | 1944 |
| 94. Гыйззәтуллин Хамазан Гатаулла улы | 1943 |
| 95. Гыйльметдинов Гайфетдин Гыйльметдин улы | 1944 |
| 96. Гыйниятуллин Габбас Гыйниятулла улы | 1943 |
| 97. Давыдов Селивёрст Васильевич | 1943 |
| 98. Даутов Искәндәр Садыйк улы | 1944 |
| 99. Дәүләтов Бакир Рәхим улы | 1944 |
| 100. Дәүләтов Баян Яркәй улы | 1943 |
| 101. Девятаев Михаил Петрович | 1957 |
| 102. Денисов Иван Фёдорович | 1945 |
| 103. Дмитриев Максим Васильевич | 1940 |
| 104. Днепров Пётр Алексеевич | 1945 |
| 105. Дряничкин Михаил Ефимович | 1945 |
| 106. Дубин Ибраһим Хөсәен улы | 1943 |
| 107. Евсеев Гавриил Петрович | 1945 |
| 108. Ежков Валентин Фёдорович | 1944 |
| 109. Елисеев Михаил Григорьевич | 1943 |
| 110. Еналиев Барый (Борис) Муса улы | 1945 |
| 111. Җәлил Муса Мостафа улы | 1946 |
| 112. Җиһангиров Мөхәммәт Солтангәрәй улы | 1944 |
| 113. Заварыкин Иван Александрович | 1944 |
| 114. Закиров Гали Закир улы | 1944 |
| 115. Заманов Хәсән Заман улы | 1944 |
| 116. Заһидуллин Фәхретдин Гыйльметдин улы | 1944 |
| 117. Засорин Иван Михайлович | 1945 |
| 118. Захаров Геннадий Михайлович | 1943 |
| 119. Зиннуров Нәбиулла Шәфикъ улы | 1944 |
| 120. Зиновьев Иван Дмитриевич | 1940 |
| 121. Ибраһимов Хәбибулла Ибраһим улы | 1940 |
| 122. Иванов Николай Петрович | 1943 |
| 123. Иванов Пётр Артемьевич | 1944 |
| 124. Ивушкин Пётр Терентьевич | 1945 |
| 125. Идрисов Гыйлемхан Идрис улы | 1945 |
| 126. Имаметдинов Мәгъсүм Имаметдин улы | 1945 |
| 127. Иовлев Владимир Александрович | 1945 |
| 128. Исаев Алексей Петрович | 1945 |
| 129. Исхаков Зиннәтулла Гыйниятулла улы | 1945 |
| 130. Ишмөхәммәдов Тамерлан Кәрим улы | 1946 |
| 131. Ишмөхәммәтов Әхмәдулла Хаҗи улы | 1944 |
| 132. Йосыпов Исмаил Әкъсан улы | 1943 |
| 133. Кабушкин Иван Константинович | 1965 |
| 134. Кадыйргалиев Леонид Иванович | 1944 |
| 135. Казаков Александр Афанасьевич | 1945 |
| 136. Казаков Анатолий Семёнович | 1946 |
| 137. Казанбаев Шәрифҗан Габдрахман улы | 1944 |
| 138. Кайманов Никита Фадеевич | 1941 |
| 139. Калашников Анатолий Степанович | 1944 |
| 140. Камалетдинов Фәррах Гыймади улы | 1943 |
| 141. Камалиев Галимҗан Камали улы | 1944 |
| 142. Карбышев Дмитрий Михайлович | 1946 |
| 143. Кардашенко Юрий Борисович | 1945 |
| 144. Катин Николай Андреевич | 1945 |
| 145. Кәлиев Әнвәр Мәди (Мәһди) улы | 1944 |
| 146. Кәримов Салават Хәким улы | 1942 |
| 147. Кержнев Таһир Кәлүк улы | 1945 |
| 148. Кирпонос Михаил Петрович | 1940 |
| 149. Кирсанов Александр Васильевич | 1944 |
| 150. Кобяков Иван Григорьевич | 1944 |
| 151. Коваль Александр Моисеевич | 1945 |
| 152. Козлов Николай Андреевич | 1942 |
| 153. Козлов Степан Игнатьевич | 1943 |
| 154. Колчанов Михаил Егорович | 1945 |
| 155. Конев Иван Никитич | 1944 |
| 156. Коновалов Семён Васильевич | 1943 |
| 157. Корбанов Алексей Габрахман улы | 1944 |
| 158. Кочнев Иван Егорович | 1945 |
| 159. Кошаев Николай Михайлович | 1944 |
| 160. Кошкин Андрей Евдокимович | 1944 |
| 161. Крайнов Степан Матвеевич | 1944 |
| 162. Красавин Михаил Васильевич | 1943 |
| 163. Ксенофонтов Александр Кузьмич | 1940 |
| 164. Кубакаев Тимерәй | 1943 |
| 165. Кудашев Идрис Моисеевич | 1940 |
| 166. Кудряшов Герасим Павлович | 1945 |
| 167. Кузнецов Анатолий Иванович | 1943 |
| 168. Кузнецов Борис Кириллович | 1944 |
| 169. Кузьмин Михаил Кузьмич | 1941 |
| 170. Кузьмин Сергей Евдокимович | 1945 |
| 171. Культин Фёдор Сергеевич | 1943 |
| 172. Кулясов Александр Петрович | 1945 |
| 173. Курасанов Пётр Семёнович | 1945 |
| 174. Кутуев Рәүф Ибраһим улы | 1945 |
| 175. Ларионов Григорий Фёдорович | 1944 |
| 176. Ларионов Семён Архипович | 1943 |
| 177. Латыйпов Габдрахман Хәким улы | 1945 |
| 178. Липатов Николай Дмитриевич | 1944 |
| 179. Лихачёв Пётр Тимофеевич | 1942 |
| 180. Майский Сәхип Нурлыгаян улы | 1940 |
| 181. Максимов Иван Тихонович | 1945 |
| 182. Максютов Сергей Павлович | 1945 |
| 183. Малышев Алексей Петрович | 1945 |
| 184. Манаков Пётр Захарович | 1943 |
| 185. Маннанов Илдар Маннан улы | 1941 |
| 186. Маринин Виктор Иванович | 1943 |
| 187. Матвеев Иван Степанович | 1945 |
| 188. Матросов Александр Матвеевич (Мөхәммәтҗанов Шакирҗан Юныс улы) | 1943 |
| 189. Машанин Григорий Михайлович | 1945 |
| 190. Машковцев Борис Вячеславович | 1966 |
| 191. Мәҗитов Гали Әхмәт улы | 1944 |
| 192. Медноногов Вячеслав Александрович | 1945 |
| 193. Меркушев Александр Максимович | 1945 |
| 194. Мизинов Михаил Петрович | 1943 |
| 195. Минаев Гатаулла Мирзаһит улы | 1945 |
| 196. Миңнеәхмәтов Нурлы Миңнеәхмәт улы | 1944 |
| 197. Миронов Павел Андреевич | 1946 |
| 198. Михайлов Василий Николаевич | 1943 |
| 199. Мозжаров Иван Иванович | 1944 |
| 200. Морзаханов Галләм Гыймади улы | 1945 |
| 201. Москвин Михаил Кириллович | 1943 |
| 202. Мосолов Георгий Константинович | 1960 |
| 203. Мостафин Михаил Андреевич | 1944 |
| 204. Мостәкыймов Зәйнулла Мөстәкыйм улы | 1945 |
| 205. Мөхәммәдиев Хәмзә Нурсәлим улы | 1943 |
| 206. Мурзин Ибрай Хөсәен улы | 1945 |
| 207. Насретдинов Гаффар Назар улы | 1945 |
| 208. Недбайло Анатолий Константинович | 1945, 1945 |
| 209. Нигъмәтуллин Гафият Ярмөхәммәт улы | 1940 |
| 210. Никитин Иван Моисеевич | 1944 |
| 211. Николаев Владимир Николаевич | 1944 |
| 212. Никоноров Пётр Михайлович | 1944 |

*1 нче кушымта (дәвамы)*

| 1 | 2 | 1 | 2 | 1 | 2 |
|---|---|---|---|---|---|
| 213. Ниятбәков Хәмит Әхмәт улы | 1943 | 257. Сафиуллин Гани Биккенә улы | 1943 | 301. Халев Василий Дмитриевич | 1945 |
| 214. Новосёлов Кузьма Васильевич | 1945 | 258. Сафронов Пётр Сергеевич | 1944 | 302. Халиков Ислам Рәхим улы | 1945 |
| 215. Ногманов Дәүләтгәрәй Сирай улы | 1945 | 259. Сәетов Гәбделхәй Сәет ул | 1945 | 303. Ханжин Павел Семёнович | 1943 |
| 216. Норкин Иван Андреевич | 1944 | 260. Сәйранов Садыйк Вилдан улы | 1945 | 304. Хәбибуллин Зәки Хәбибулла улы | 1945 |
| 217. Нугаев Нәҗип Ногман улы | 1943 | 261. Сентюков Николай Петрович | 1943 | 305. Хәйдәршин Гайнан Хәйдәрша улы | 1944 |
| 218. Нуркәев Талип Латыйп улы | 1944 | 262. Сергеев Александр Терентьевич | 1945 | 306. Хәйретдинов Әкрам Минһаҗ улы | 1945 |
| 219. Одноценов Герман Петрович | 1945 | 263. Сергеев Александр Тимофеевич | 1945 | 307. Хәйретдинов Минһаҗ Хәйретдин улы | 1945 |
| 220. Осипов Василий Иванович | 1943 | 264. Сергеев Михаил Егорович | 1945 | 308. Хәйруллин Хәбибулла Нәбиулла улы | 1945 |
| 221. Осипов Илья Тимофеевич | 1944 | 265. Сибгатуллин Лотфулла Сибай улы | 1943 | 309. Хәйруллин Хәлил Зиннәтулла улы | 1945 |
| 222. Павлов Григорий Родионович | 1943 | 266. Сигов Василий Иванович | 1945 | 310. Хәкимов Михаил (Исмәгыйль) | |
| 223. Палагин Владимир Степанович | 1946 | 267. Симонов Михаил Васильевич | 1942 | Кәбир улы | 1945 |
| 224. Панарин Михаил Петрович | 1944 | 268. Синдряков Николай Кузьмич | 1943 | 311. Хәлиуллин Мисбах Хәлиулла улы | 1945 |
| 225. Панфилов Алексей Павлович | 1945 | 269. Ситдыйков Касыйм Хәсән улы | 1945 | 312. Хәсәнов Хатыйп Хөсәен улы | 1943 |
| 226. Пейсаховский Наум Григорьевич | 1945 | 270. Соболев Николай Леонтьевич | 1943 | 313. Хәсәншин Мансур Рәхип улы | 1944 |
| 227. Петров Владимир Александрович | 1945 | 271. Соколов Леонид Михайлович | 1945 | 314. Хөсәенов Зәкәри Сәфит улы | 1945 |
| 228. Петров Михаил Петрович | 1945 | 272. Соколов Сергей Николаевич | 1944 | 315. Цаплин Павел Алексеевич | 1937 |
| 229. Петухов Игнатий Павлович | 1943 | 273. Солтанов Закир | 1945 | 316. Чалдаев Виктор Алексеевич | |
| 230. Петушков Адам Захарович | 1944 | 274. Спирьков Степан Петрович | 1940 | (Вәлиулла Али улы) | 1944 |
| 231. Пискунов Василий Григорьевич | 1944 | 275. Староверов Яков Петрович | 1943 | 317. Чекин Борис Сергеевич | 1945 |
| 232. Полушкин Пётр Алексеевич | 1945 | 276. Столяров Николай Георгиевич | 1944, 1945 | 318. Чепуренко Анатолий Алексеевич | 1940 |
| 233. Привалов Дмитрий Карпович | 1943 | 277. Строганов Дмитрий Евгеньевич | 1940 | 319. Чирков Михаил Алексеевич | 1943 |
| 234. Просвирнин Михаил Андреевич | 1944 | 278. Суднишников Михаил Владимирович | 1945 | 320. Чулков Алексей Петрович | 1942 |
| 235. Радугин Феофан Григорьевич | 1948 | 279. Сыртланова Мәгубә Хөсәен кызы | 1946 | 321. Чунтонов Николай Григорьевич | 1944 |
| 236. Рамаев Гаяз Галиәскәр улы | 1944 | 280. Тапиков Самуил Михайлович | 1945 | 322. Шабалин Борис Сергеевич | 1945 |
| 237. Рәхимов Бакый Сибгатулла улы | 1940 | 281. Токарликов Никита Евдокимович | 1945 | 323. Шамкаев Әкрам Билал улы | 1944 |
| 238. Рәхмәтуллин Шамил Сәет улы | 1944 | 282. Уганин Семён Артемьевич | 1944 | 324. Шәмсетдинов Гали Нурулла улы | 1944 |
| 239. Родионов Пётр Зиновьевич | 1945 | 283. Умеркин Габделхак Сәгыйть улы | 1942 | 325. Шаһгалиев Фәрит Солтан улы | 1982 |
| 240. Родных Михаил Васильевич | 1943 | 284. Фадеев Сергей Михайлович | 1943 | 326. Шаһивәлиев Галимҗан Нургаяз улы | 1945 |
| 241. Романов Григорий Григорьевич | 1945 | 285. Фазлаев Нурулла Гарифулла улы | 1945 | 327. Шаповалов Александр Тимофеевич | 1944 |
| 242. Рудаков Александр Павлович | 1944 | 286. Фәйзуллин Җиһанша Закир улы | 1945 | 328. Шафранов Пётр Григорьевич | 1945 |
| 243. Русаков Климент Сергеевич | 1945 | 287. Фәйзуллин Хәниф Шакир улы | 1944 | 329. Шәймәрданов Зәки Шәймәрдан улы | 1944 |
| 244. Рыжов Михаил Григорьевич | 1943 | 288. Фәткуллин Әнвәр Әсәдулла улы | 1945 | 330. Шәкүров Яков Савельевич | 1945 |
| 245. Рыжов Михаил Иванович | 1946 | 289. Фәткуллин Фәрит Мөхәммәтҗан улы | 1941 | 331. Шәрипов Нурми Хәләф улы | 1944 |
| 246. Сабиров Фәйзерахман Әхмәтҗан улы | 1945 | 290. Федин Михаил Александрович | 1944 | 332. Шәрипов Фатих Зариф улы | 1944 |
| 247. Сабиров Хафиз Сабир улы | 1940 | 291. Фёдоров Иван Михайлович | 1945 | 333. Шульгин Борис Владимирович | 1945 |
| 248. Савельев Фёдор Петрович | 1945 | 292. Федосеев Михаил Андреевич | 1942 | 334. Юнысов Нәбиулла Зәйнулла улы | 1944 |
| 249. Садриев Самат Сәлах улы | 1944 | 293. Филиппов Гордей Иванович | 1945 | 335. Юхвитов Пётр Сергеевич | 1945 |
| 250. Сажинов Виктор Александрович | 1945 | 294. Фильченков Сергей Яковлевич | 1944 | 336. Яковлев Евстафий Григорьевич | 1945 |
| 251. Салихов Гатаулла Салих улы | 1943 | 295. Фомин Михаил Сергеевич | 1943 | 337. Якупов Камил (Николай) Якуп улы | 1944 |
| 252. Салихов Мидхәт Габдулла улы | 1944 | 296. Фролов Павел Григорьевич | 1945 | 338. Якупов Назыйм Мөхәммәтҗан улы | 1956 |
| 253. Самочкин Анатолий Васильевич | 1942 | 297. Һадимөхәммәтов Гомәр Мостафа улы | 1944 | 339. Яницкий Василий Иванович | 1942 |
| 254. Санфирова Ольга Александровна | 1945 | 298. Хәбиев Вильдан Сәет улы | 1943 | 340. Янтимеров Булат Янбулат улы | 1944 |
| 255. Сафин Накыйп Сафа улы | 1943 | 299. Хаҗиев Вәли Хаҗиәхмәт улы | 1944 | 341. Яһүдин Кәрим Мусакай улы | 1938 |
| 256. Сафин Нурулла Дәүләтгәрәй улы | 1945 | 300. Хаҗипов Нәҗип Хаҗип улы | 1945 | 342. Яшин Георгий Филиппович | 1944 |

*2 нче кушымта*

## РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ГЕРОЙЛАРЫ

| Фамилиясе, исеме, әтисе исеме | Бирелү елы | Фамилиясе, исеме, әтисе исеме | Бирелү елы | Фамилиясе, исеме, әтисе исеме | Бирелү елы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Абдуллин Раушан Әхмәт улы | 2009 | 12. Ихсанов Рәфыйк Рәшит улы | 2000 | 23. Сәхәбетдинов Риф Рәис улы | 2001 |
| 2. Алимов Владимир Ришат улы | 2000 | 13. Козин Алексей Владимирович | 1999 | 24. Сиражетдинов Тимур Гали улы | 2000 |
| 3. Алыков Марат Равил улы | 1998 | 14. Кораблёв Алексей Михайлович | 2000 | 25. Смирнов Георгий Семёнович | 2008 |
| 4. Әхмәтшин Марат Радик улы | 2016 | 15. Корбангалиев Артур Ришат улы | 1999 | 26. Супонинский Александр Анатольевич | 2000 |
| 5. Бариев Радик Әбрар улы | 2006 | 16. Мостафин Рәис Рәүф улы | 2000 | 27. Тулин (Гыйззәтуллин) Сергей (Риф) | |
| 6. Закиров Илфат Индулис улы | 2001 | 17. Мөхәммәдгәрәев Венер Мансур улы | 2008 | Заһит улы | 1996 |
| 7. Зарипов Альберт Марат улы | 1996 | 18. Мөхетдинов Тимур Мөхәммәтсабир улы | 2011 | 28. Уразаев Игорь Кәбир улы | 1995 |
| 8. Епанешников Александр Николаевич | 1994 | 19. Нургалиев Владимир Вил улы | 2000 | 29. Хәйруллин Газинур Гарифҗан улы | 1996 |
| 9. Ерин Виктор Фёдорович | 1993 | 20. Рәфыйков Мансур Миңнебай улы | 1996 | 30. Шарпатов Владимир Ильич | 1996 |
| 10. Ибраһимов Тимур Франил улы | 2009 | 21. Сафин Дмитрий Анатольевич | 2001 | 31. Якупов Фәрват Габдулла улы | 1995 |
| 11. Исаев Олег Николаевич | 1996 | 22. Сафин Ильяс Дилшат улы | 2009 | 32. Яфәров Җәфәс Җәфәр улы | 2000 |

*3 нче кушымта*

## СОЦИАЛИСТИК ХЕЗМӘТ ГЕРОЙЛАРЫ

| Фамилиясе, исеме, әтисе исеме | Бүләкләнү елы |
|---|---|
| 1. Абдуллин Нигъмәтулла Төхфәтулла улы | 1981 |
| 2. Алиев Госман Гатаулла улы | 1973 |
| 3. Арбузов Александр Ерминингельдович | 1957 |
| 4. Арбузов Борис Александрович | 1969 |
| 5. Арестов Анатолий Васильевич | 1971 |
| 6. Аристов Фёдор Сергеевич | 1971 |
| 7. Әбдриев Әхмәтгәрәй Шакирҗан улы | 1971 |
| 8. Әбүбәкеров Гәрәйша Дәүләтша улы | 1971 |
| 9. Әгъләмов Нәгыйм Харислам улы | 1977 |
| 10. Әһлуллин Рәүф Габдулла улы | 1966 |
| 11. Әсхәдуллин Галимулла Әсхәдулла улы | 1974 |
| 12. Әсхәдуллин Фидус Фәез улы | 1977 |
| 13. Әфләтунова Фатыйма Фәрди кызы | 1966 |
| 14. Әхмәдиева Ганҗә Галим кызы | 1980 |
| 15. Әхмәдуллин Исмәгыйль Ибраһим улы | 1966 |
| 16. Әхмәтов Дамир Рәхми улы | 1966 |
| 17. Багаева Евдокия Николаевна | 1973 |
| 18. Баев Александр Александрович | 1981 |
| 19. Бакыева Һава Хәмидулла кызы | 1974 |
| 20. Баһманов Гәрәй Мәүлетбай улы | 1966 |
| 21. Бариев Нургали Барый улы | 1966 |
| 22. Батенчук Евгений Никонорович | 1981 |
| 23. Батыршин Нәкый Курамша улы | 1966 |
| 24. Баштанюк Геннадий Сергеевич | 1986 |
| 25. Белявский Георгий Александрович | 1966 |
| 26. Беспалова Александра Николаевна | 1966 |
| 27. Бирюлин Александр Иванович | 1988 |
| 28. Борһанов Әбрар Хәмит улы | 1966 |
| 29. Боровиков Геннадий Петрович | 1981 |
| 30. Булатов Алмас Харис улы | 1971 |
| 31. Булгаков Ришат Тимергали улы | 1976 |
| 32. Бутома Борис Евстафьевич | 1959 |
| 33. Ваһапов Ядкәр Сәхап улы | 1971 |
| 34. Васильев Лев Борисович | 1977 |
| 35. Вахитов Акмал Гыйльфан улы | 1948 |
| 36. Вәлиев Корбан Агап улы | 1959 |
| 37. Вәлиханов Әгъзам Вәлихан улы | 1971 |
| 38. Витер Пётр Акимович | 1971 |
| 39. Вишневский Александр Александрович | 1966 |
| 40. Вырин Василий Филиппович | 1966 |
| 41. Габбасов Сәет Фәйзерахман улы | 1973 |
| 42. Габдрахманова Стелла Зәки кызы | 1978 |
| 43. Габдрәхимов Газиз Габдрәхим улы | 1948 |
| 44. Галиәхмәтов Габделхәй Халик улы | 1984 |
| 45. Галиәхмәтов Таһир Әхмәт улы | 1971 |
| 46. Галиев Габделхак Гали улы | 1966 |
| 47. Галиев Гайфетдин Сәләхетдин улы | 1971 |
| 48. Галиев Шакир Гали улы | 1971 |
| 49. Галимова Дания Һадиҗан кызы | 1971 |
| 50. Галочкина Надежда Николаевна | 1966 |
| 51. Гарипов Әсгать Гариф улы | 1971 |
| 52. Гарифуллин Бари Гарифулла улы | 1952 |
| 53. Гатауллин Самат Сәмигулла улы | 1981 |
| 54. Гаязова Гөлсылу Хәлил кызы | 1974 |
| 55. Гәрәев Рафаил Закир улы | 1971 |
| 56. Герасименко Виктор Иванович | 1963 |
| 57. Глебов Михаил Никодимович | 1971 |
| 58. Гобәйдуллин Әхәт Шәрифулла улы | 1959 |
| 59. Гобәйдуллин Сафиулла Сәлимулла улы | 1971 |
| 60. Гозәеров Камил Сабир улы | 1971 |
| 61. Григорьев Вениамин Демьянович | 1981 |
| 62. Гринь Михаил Петрович | 1959 |
| 63. Гыйзәтдинов Лотфулла Вәли улы | 1971 |
| 64. Гыйләҗев Наил Минһаҗ улы | 1971 |
| 65. Гыйльманов Сәгыйрь Гыйльман улы | 1971 |
| 66. Гыймазов Мөгаллим Минһаҗ улы | 1959 |
| 67. Гыйматдинов Габбас Кыям улы | 1971 |
| 68. Давыденко Иван Миронович | 1973 |
| 69. Дәүләтчина Мингәләм Зәйни кызы | 1966 |
| 70. Дементьев Пётр Васильевич | 1941, 1977 |
| 71. Демухаметов Николай Александрович | 1948 |
| 72. Дергунов Лазарь Васильевич | 1948 |
| 73. Драцкий Николай Григорьевич | 1966 |
| 74. Евдокимова Антонина Ивановна | 1948 |
| 75. Ефимов Валентин Владимирович | 1966 |
| 76. Ефремов Александр Ефремович | 1948 |
| 77. Журин Иван Иванович | 1959 |
| 78. Җантимерова Гөлсинә Хөснулла кызы | 1976 |
| 79. Җәләев Радик Инсаф улы | 1977 |
| 80. Җиһанов Нәҗип Гаяз улы | 1981 |
| 81. Җиһаншин Әхмәтша Җиһанша улы | 1948 |
| 82. Закиров Нәгыйм Сафа улы | 1966 |
| 83. Заһидуллин Рәис Газиз улы | 1966 |
| 84. Заһирова Сания Сабир кызы | 1966 |
| 85. Зарипов Рим Ибраһим улы | 1986 |
| 86. Зарипова Тәүзиха Гәрәй кызы | 1971 |
| 87. Зарифов Абдрахман Зариф улы | 1968 |
| 88. Захаров Николай Иванович | 1971 |
| 89. Зәйдуллин Хәмит Вәли улы | 1966 |
| 90. Зәйнагов Җәмил Сирай улы | 1966 |
| 91. Зәйнуллин Насыйфулла Гыйззәтулла улы | 1971 |
| 92. Зотов Михаил Егорович | 1948 |
| 93. Зыятдинов Нәҗип Зыятдин улы | 1976 |
| 94. Ибәтуллин Кәримулла Хәким улы | 1966 |
| 95. Иванов Иван Захарович | 1985 |
| 96. Иванцов Николай Максимович | 1972 |
| 97. Иманов Зөфәр Минтимер улы | 1984 |
| 98. Йосыпов Хәмит Габбас улы | 1958 |
| 99. Исаев Алексей Степанович | 1971 |
| 100. Исламгалиев Мөдәррис Габдулла улы | 1977 |
| 101. Капитонов Николай Михайлович | 1971 |
| 102. Карпов Михаил Васильевич | 1966 |
| 103. Кашапов Зәкәрия Кәшшаф улы | 1966 |
| 104. Каюмов Габдерәүф Габделхак улы | 1966 |
| 105. Кәлимуллин Рифкать Кәлимулла улы | 1951 |
| 106. Кәлимуллина Мәгъсүмә Садри кызы | 1966 |
| 107. Кәримов Фәхразый Шәмсемөхәммәт улы | 1981 |
| 108. Кәримова Гөлбикә Гәрәй кызы | 1971 |
| 109. Кәримова Саимә Сафа кызы | 1976 |
| 110. Копылов Виталий Егорович | 1971 |
| 111. Королёв Евгений Никифорович | 1971 |
| 112. Кузьмина Екатерина Антоновна | 1966 |
| 113. Кушмөхәммәтов Гариф Зариф улы | 1957 |
| 114. Латыйпов Госман Хафиз улы | 1971 |
| 115. Леванов Владимир Алексеевич | 1971 |
| 116. Лемаев Николай Васильевич | 1980 |
| 117. Линькова Клавдия Александровна | 1948 |
| 118. Лисин Николай Викторович | 1966 |
| 119. Лисов Иван Игнатьевич | 1971 |
| 120. Лукин Макар Михайлович | 1945 |
| 121. Лушников Владимир Петрович | 1971 |
| 122. Максимов Николай Иванович | 1966 |
| 123. Маликов Габдуллаҗан Габделхак улы | 1966 |
| 124. Маликова Әминә Малик кызы | 1966 |
| 125. Малиновский Михаил Сергеевич | 1971 |
| 126. Малышева Клавдия Филипповна | 1966 |
| 127. Мальнёв Николай Дмитриевич | 1981 |
| 128. Маслов Георгий Дмитриевич | 1963 |
| 129. Мәүлиев Мисбах Мәүли улы | 1966 |
| 130. Мәүликов Вазил Салих улы | 1981 |
| 131. Минһаҗева Гөлсем Мифтах кызы | 1960 |
| 132. Миңлекәев Мәсгут Габдрахман улы | 1966 |
| 133. Миңнегулов Госан | 1948 |
| 134. Мокшин Александр Фёдорович | 1971 |
| 135. Мөрсәлимов Фәтрахман Хәбибрахман улы | 1966 |
| 136. Мөхәммәтдинов Шамил Галиәхмәт улы | 1971 |
| 137. Мөхәммәтҗанова Легия Файзерахман кызы | 1971 |
| 138. Мусин Лотфулла Ногман улы | 1971 |
| 139. Насыйбуллин Минзаһир Насыйбулла улы | 1957 |
| 140. Нәфыйкова Сәрвәр Нәфыйк кызы | 1967 |
| 141. Немасев Сергей Егорович | 1957 |
| 142. Низаметдинов Равил Мифтах улы | 1990 |
| 143. Никитин Семён Павлович | 1959 |
| 144. Никитина Евдокия Тимофеевна | 1960 |
| 145. Николаева Александра Ивановна | 1948 |
| 146. Новолодский Алексей Борисович | 1971 |
| 147. Нуретдинов Дамир Мәхмүт улы | 1980 |
| 148. Павлов Александр Алексеевич | 1976 |
| 149. Петров Леонтий Степанович | 1966 |
| 150. Полющенков Григорий Григорьевич | 1966 |
| 151. Прохоренко Дмитрий Фёдорович | 1958 |
| 152. Прохоров Василий Никитович | 1966 |
| 153. Рахмангулов Зәки Салават улы | 1966 |
| 154. Речапова Мансура Габдрахман кызы | 1971 |
| 155. Рожков Пётр Кузьмич | 1980 |
| 156. Сабирҗанов Габдулла Сабирҗан улы | 1948 |
| 157. Савельев Павел Фёдорович | 1966 |
| 158. Садовников Владимир Геннадиевич | 1976, 1981 |
| 159. Садыкова Зәйнәп Садыйк кызы | 1966 |
| 160. Сакаева Мәстүрә Фәхретдин кызы | 1969 |
| 161. Сальников Александр Лаврентьевич | 1966 |
| 162. Саттаров Рәшит Саттар улы | 1958 |
| 163. Сафин Вафа Сафа улы | 1971 |
| 164. Сафин Гәрәй Сафа улы | 1947 |
| 165. Сафин Зәкәрия Зөфәр улы | 1986 |
| 166. Сафиуллин Әнвәр Шакирҗан улы | 1973 |
| 167. Сәгъдиев Ногман Дәрземан улы | 1948 |
| 168. Сәгъдуллин Шәрифулла Сәгъдулла улы | 1976 |
| 169. Сәлимҗанов Галимҗан Закирҗан улы | 1971 |
| 170. Седов Александр Осипович | 1966 |
| 171. Сергиевский Константин Александрович | 1971 |
| 172. Сибиркин Анатолий Сергеевич | 1964 |
| 173. Смирнова Любовь Евгеньевна | 1981 |
| 174. Соболев Николай Алексеевич | 1971 |
| 175. Солнцева Вера Васильевна | 1976 |
| 176. Сорокина Валентина Васильевна | 1976 |
| 177. Сторожев Георгий Степанович | 1948 |
| 178. Таҗиева Миңлесәгыйрә Таҗи кызы | 1971 |
| 179. Тимерҗанов Зәки Тимерҗан улы | 1971 |
| 180. Тимченко Александр Григорьевич | 1959 |
| 181. Тиханкова Анастасия Ивановна | 1972 |
| 182. Турунтаева Мария Сергеевна | 1971 |
| 183. Тюнин Николай Андриянович | 1977 |
| 184. Филимонов Виктор Петрович | 1977 |
| 185. Фоменко Владислав Александрович | 1977 |
| 186. Фролов Николай Васильевич | 1971 |
| 187. Хабаров Андрей Александрович | 1958 |
| 188. Хаҗиәхмәтов Вагыйзь Хаҗиәхмәт улы | 1966 |
| 189. Хаҗиев Галимҗан Мөхәммәтша улы | 1971 |
| 190. Халезов Павел Александрович | 1966 |
| 191. Хафизов Шәриф Сәгыйрь улы | 1966 |
| 192. Хәйруллина Миңнура Гали кызы | 1966 |
| 193. Хәмидуллин Салих Сөнгать улы | 1960 |
| 194. Хәсәнов Закир Шакир улы | 1976 |
| 195. Хәсәншина Газифә Хәсән кызы | 1969 |
| 196. Хәстиев Мирбат Бәдри улы | 1984 |
| 197. Хисаметдинов Госман Камали улы | 1966 |
| 198. Хөсәенов Мәгъсүм Шәйгазам улы | 1966 |
| 199. Хөснетдинова Мария Николаевна | 1966 |
| 200. Чегодаева Клавдия Константиновна | 1966 |
| 201. Шакиров Гыйльми Шакир улы | 1981 |
| 202. Шаһиәхмәтов Әхмәдулла Кәримулла улы | 1966 |
| 203. Шәймәрданов Галим Шәймәрдан улы | 1977 |
| 204. Шәйхетдинов Илсур Гәрәфи улы | 1975 |
| 205. Шәйхиева Мәрфуга Шәйхи кызы | 1975 |
| 206. Шәрәфетдинов Фәсхетдин Мөхетдин улы | 1966 |
| 207. Шәрифуллин Даһи Гарифулла улы | 1966 |
| 208. Шәрифуллин Зиннәт Галиулла улы | 1966 |
| 209. Юсипов (Йосыпов) Шамил Сафа улы | 1973 |
| 210. Ягъфәров Сабит Фатих улы | 1975 |

*4 нче кушымта*

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ БҮЛӘГЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

| Фамилиясе, исеме, әтисе исеме | Бүләкләнү елы |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Абызгилдин Абрек Әмир улы | 1997 |
| 2. Абязов Рөстәм Юныс улы | 2003 |
| 3. Авзалова Әлфия Авзал кызы | 1992 |
| 4. Агади Әхмәд Илтифад углы | 2008 |
| 5. Айдаров Ильяс Сәяр улы | 2013 |
| 6. Андреев Роберт Егорович | 2008 |
| 7. Андреева Кристина Андреевна | 2015 |
| 8. Арсланов Айрат Гәрәй улы | 1969 |
| 9. Арсланов Нури Газиз улы | 1985 |
| 10. Артамонов Илья Николаевич | 2016 |
| 11. Аршинов Виктор Петрович | 2008 |
| 12. Афзалов Гамил Гыймазетдин улы (Гамил Афзал) | 1977 |
| 13. Ахиярова Резеда Зәки кызы | 2008 |
| 14. Ахунов Гарифҗан Ахунҗан улы | 1973 |
| 15. Әбҗәлилов Хәлил Гали улы | 1958 |
| 16. Әгъләметдинов Мөдәррис Зөфәр улы (Мөдәррис Әгъләмов) | 1992 |
| 17. Әмиров Мирсәяф Мәсәлим улы (Мирсәй Әмир) | 1974 |
| 18. Әпсәләмов Габдрахман Сафа улы | 1959 |
| 19. Әсәдуллин Альберт Әхәт улы | 2002 |
| 20. Әсфәндиярова Шаһсәнәм Ибраһимбәк кызы | 1966 |
| 21. Әхмәтҗанов Илдус Хәниф улы | 2000 |
| 22. Әхмәтҗанов Роберт Вәли улы | 2001 |
| 23. Әхмәтов Фасил Әхмәтгали улы | 1988 |
| 24. Әхмәтова Флора Ваһап кызы | 1989 |
| 25. Бакиров Әнвәр Закир улы | 1973 |
| 26. Бакулин Герман Алексеевич | 1981 |
| 27. Батуллин Роберт Мөхлис улы (Рабит Батулла) | 2006 |
| 28. Батыркаева Луиза Миңнегали кызы (Луиза Батыр-Болгари) | 2006 |
| 29. Баянов Әхсән Фәтхелбаян улы | 1999 |
| 30. Бәширов Гомәр Бәшир улы | 1996 |
| 31. Беспалов Виктор Иванович | 1977 |
| 32. Бигичев Хәйдәр Аббас улы | 1984 |
| 33. Биктимеров Шәүкәт Хәсән улы | 1966 |
| 34. Бикчәнтәев Рәфкат Әхмәтҗан улы | 1960 |
| 35. Бикчәнтәев Фәрит Рәфкат улы | 1998 |
| 36. Бохараев Равил Рәис улы | 2006 |
| 37. Бугров Дмитрий Геннадьевич | 2016 |
| 38. Булатова Клара Гариф кызы | 2015 |
| 39. Бурлай Алексей Петрович | 1960 |
| 40. Васильев Владимир Михайлович | 1984 |
| 41. Вахитов Габделхәй Каюм улы (Хәй Вахит) | 1960 |
| 42. Вәлиев Диас Назыйх улы | 1976 |
| 43. Вәлиев Разил Исмәгыйль улы | 2007 |
| 44. Вәлиуллин Фәрит Рәшит улы | 2016 |
| 45. Вәлиуллин Хөснулла Вәлиулла улы | 1989 |
| 46. Гайнуллина Алсу Әскар кызы | 2013 |
| 47. Галиев Марсель Баян улы | 2006 |
| 48. Галицкий Михаил Олегович | 2000 |
| 49. Ганиева Венера Әхәт кызы | 1997 |
| 50. Гатауллин Рәдиф Кәшфулла улы (Рәдиф Гаташ) | 2008 |
| 51. Гәрәева Нелли Хәким кызы (Наилә Гәрәева) | 1966 |
| 52. Гельмс Эрнст Брунович | 1966 |
| 53. Гыйләҗев Аяз Мирсәет улы | 1983 |
| 54. Гыймаев Зөфәр Фоат улы | 2005 |
| 55. Гыйматдинова (Бикчурова) Нәбирә Миннәхмәт кызы | 2013 |
| 56. Даутов Нияз Курамша улы | 1958 |
| 57. Дунаев Николай Иванович (Наил Дунаев) | 1998 |
| 58. Еникиев Әмирхан Нигъмәтҗан улы (Әмирхан Еники) | 1984 |
| 59. Еникиев Ренат Әхмәт улы | 1983 |
| 60. Жиһанов Нәҗип Гаяз улы | 1958 |
| 61. Җамалетдинов Ленар Шәйхи улы | 1989 |
| 62. Зарипов Илдар Касыйм улы | 1994 |
| 63. Зарипов Марат Нәби улы | 2002 |
| 64. Зарипов Марсель Харис улы | 1987 |
| 65. Зәйдуллин Ркаил Рафаил улы (Ркаил Зәйдулла) | 2010 |
| 66. Зәйнашева Гөлшат Хисам кызы | 1991 |
| 67. Зәкиев Әүфәр Зәки улы | 1981 |
| 68. Зәнкиев Якуб Камали улы | 2002 |
| 69. Ибраһимов Илфак Мирза улы (Мөхәммәт Мирза) | 2011 |
| 70. Ибраһимов Ренат Ислам улы | 1979 |
| 71. Имамов Вахит Шәех улы | 2014 |
| 72. Индюхов Николай Петрович | 2006 |
| 73. Исәнбәт Нәкый Сираҗетдин улы | 1968 |
| 74. Исмәгыйлев Нәҗип Фәйзрахман улы (Нәҗип Нәкъкаш) | 2016 |
| 75. Ихсанова (Миңнуллина) Нәҗибә Гыймаделислам кызы | 1998 |
| 76. Камалов Хисам Нуретдин улы | 1986 |
| 77. Кәлимуллин Рәшит Фәһим улы | 2007 |
| 78. Кәримуллин Әбрар Гыйбадулла улы | 1991 |
| 79. Килдебәков Рөстәм Әхмәт улы | 2011 |
| 80. Килдебәкова Мария Семёновна | 2011 |
| 81. Ключарёв Александр Сергеевич | 1970 |
| 82. Кноблок Борис Георгиевич | 1973 |
| 83. Ковтун Георгий Анатольевич | 2015 |
| 84. Колбарисов Фатих Әкрәм улы | 1958 |
| 85. Колмогорцева Ирина Константиновна | 2015 |
| 86. Кудашева Фәридә Яһүдә кызы | 1996 |
| 87. Кудelькин Виктор Иванович | 1986 |
| 88. Кузаева Дамира Нәҗмиҗан кызы | 1979 |
| 89. Кузин Евгений Андриянович | 1981 |
| 90. Кузнецов Николай Дмитриевич | 1971 |
| 91. Кузьминых София Даниловна | 2013 |
| 92. Леухин Александр Петрович | 2016 |
| 93. Липкин Семён Израилевич | 1992 |
| 94. Луппов Анатолий Борисович | 1999 |
| 95. Лывин Сергей Осипович | 1978 |
| 96. Маликов Васил Малик улы | 1980 |
| 97. Маликов Дөлфәт Госман улы (Зөлфәт) | 2000 |
| 98. Мансуров Зиннур Мөҗип улы | 2009 |
| 99. Мансуров Фуат Шакир улы | 1994 |
| 100. Мәһдиев Мөхәммәт Сөнгат улы | 1990 |
| 101. Мәхмүтов Хуҗиәхмәт Шаһиәхмәт улы | 1989 |
| 102. Мингазиев Ибраһим Зариф улы (Ибраһим Гази) | 1969 |
| 103. Мингалимов Рөстәм Гали улы (Рөстәм Мингалим) | 2005 |
| 104. Миңнулина Асия Минвәли кызы | 2010 |
| 105. Миңнуллин Роберт Мөгаллим улы | 1998 |
| 106. Миңнуллин Туфан Габдулла улы | 1979 |
| 107. Мозаффаров Мансур Әхмәт улы | 1959 |
| 108. Монасыйпов Алмаз Закир улы | 1991 |
| 109. Монасыйпов Камил Хәмит улы | 2002 |
| 110. Монасыйпов Шамил Хәмит улы | 2002 |
| 111. Моратов Газинур Вәсыйк улы (Газинур Морат) | 2016 |
| 112. Мостафин Рафаэль Әхмәт улы | 2006 |
| 113. Мөлеков Бату Гатаулла улы | 1984 |
| 114. Мөхәммәдиев Ринат Сафа улы | 1993 |
| 115. Мөхәммәтҗанов Рәүфәл Сабир улы | 2015 |
| 116. Муллашев Камил Вәлиәхмәт улы | 2009 |
| 117. Надыйров Илбарис Нурислам улы | 1989 |
| 118. Насретдинов Фәхри Хөсәен улы | 1959 |
| 119. Нигъмәтҗанов Мәхмүт Нигъмәтҗан улы | 1985 |
| 120. Нигъмәтуллина Марина Викторовна | 2007 |
| 121. Нигъмәтуллина Рада Хөсәен кызы | 2007 |
| 122. Нуруллин Ибраһим Зиннәт улы | 1982 |
| 123. Өметбаев Сабир Гаделҗан улы | 1960 |
| 124. Панджавидзе Михаил Александрович | 2008 |
| 125. Парамонов Игорь Петрович | 1981 |
| 126. Патраков Александр Михайлович | 2000 |
| 127. Попов Владимир Александрович | 2014 |
| 128. Провоторов Николай Сергеевич | 1959 |
| 129. Прытков Геннадий Николаевич | 2009 |
| 130. Рәкыйпов Роберт Җиһанша улы | 2008 |
| 131. Рәсүлев Атилла Кадыйр улы (Атилла Расих) | 1981 |
| 132. Рәфыйков Искәндәр Вәлиулла улы | 2002 |
| 133. Рогожина Изабелла Викторовна | 2007 |
| 134. Родионов Григорий Васильевич (Гәрәй Рәхим) | 1984 |
| 135. Романова (Славутская) Светлана Геннадьевна | 2009 |
| 136. Садриев Фоат Миңлеәхмәт улы | 2010 |
| 137. Садыйков Ревдар Фәез улы | 1973 |
| 138. Садыйкова Сара Гариф кызы | 1990 |
| 139. Салахов Ибраһим Низам улы | 1990 |
| 140. Сарымсаков Ширияздан Мөхәммәтҗан улы | 1958 |
| 141. Сәлимҗанов Марсель Хәким улы | 1971 |
| 142. Ситдыйков Айрат Габит улы | 2016 |
| 143. Скоморохов Сергей Геннадьевич | 2009 |
| 144. Славутский Александр Яковлевич | 2000 |
| 145. Смирнов Игорь Валентинович | 1973 |
| 146. Соболев Виктор Евгеньевич | 2008 |
| 147. Сөнгатуллина Зилә Даян кызы | 1984 |
| 148. Таҗетдинов Ринат Арифҗан улы | 1966 |
| 149. Тимаев Михаил Иванович | 2015 |
| 150. Тимербулатов Шамил Харис улы | 2013 |
| 151. Төхфәтуллин Рамил Чыңгыз улы | 2009 |
| 152. Тумашев Әнәс Ибраһим улы | 1958 |
| 153. Тумашев Равил Рәхим улы | 1976 |
| 154. Туфан Хәсән Фәхри улы | 1966 |
| 155. Урманче Бакый Идрис улы | 1966 |
| 156. Фазлуллин Хәсби Вәлиулла улы | 1973 |
| 157. Фәйзуллин (Фәйзи) Әхмәт Әхмәтсафа улы | 1958 |
| 158. Фәйзуллин (Фәйзи) Җәүдәт Харис улы | 1966 |
| 159. Фәйзуллин Әнәс Нурулла улы | 1981 |
| 160. Фәйзуллин Равил Габдрахман улы | 1978 |
| 161. Фәттахов Лотфулла Габделмән улы | 1958 |
| 162. Фәттахов Нурихан Садрилмән улы | 1994 |
| 163. Фәтхетдинов Әхсән Сәрим улы | 1993 |
| 164. Фәтхетдинов Салават Зәки улы | 2008 |
| 165. Федотов Владимир Сергеевич | 2010 |
| 166. Федотов Юрий Степанович | 1981 |
| 167. Һидиятуллин Шәүкәт Гали улы (Шәүкәт Галиев) | 1972 |
| 168. Хаҗиәхмәтов Тавил Гыйният улы | 1987 |
| 169. Халиков Фиринат Гаптехәй улы | 2006 |
| 170. Ханов Илдар Мәнсәви улы | 2010 |
| 171. Харисов Ринат Мәгъсүм улы (Ринат Харис) | 1997 |
| 172. Хәбибуллин Заһид Вәли улы | 1968 |
| 173. Хәбибуллин Мөсәгыйть Мөдәррис улы | 2003 |
| 174. Хәйретдинов Рамил Равил улы | 2016 |
| 175. Хәйруллина Асия Хәсән кызы | 1958 |
| 176. Хәкимов Сибгат Таҗи улы (Сибгат Хәким) | 1960 |

*4 нче кушымта (дәвамы)*

| 1 | 2 | 1 | 2 | 1 | 2 |
|---|---|---|---|---|---|
| 177. Хәкимова Ирина Шәриф кызы | 1977 | 187. Шакиров Әзһәр Шәфикъ улы | 1998 | 199. Якупов Харис Габдрахман улы | 1958 |
| 178. Хәкимханов Зөлфәт Зөфәр улы (Зөлфәт Хәким) | 2009 | 188. Шакиров Илһам Гыйльметдин улы | 1970 | 200. Ярмөхәммәтов Хәмит Хөснетдин улы (Хәмит Ярми) | 1989 |
| 179. Хәсәнов Мәхмүт Максуд улы | 1988 | 189. Шаһиморатова Альбина Әнвәр кызы | 2011 | 201. Яруллин Фәнис Гатаулла улы | 1995 |
| 180. Хәсәнов Рим Мәхмүт улы | 2009 | 190. Шәйдуллин Шамил Мортаза улы | 2000 | 202. Яруллин Фәрит Заһидулла улы | 1958 |
| 181. Хисаметдинова Сания Шәкүр кызы | 1981 | 191. Шәрәфиев Равил Шиһап улы | 1992 | 203. Яхин Рөстәм Мөхәммәтхаҗи улы | 1959 |
| 182. Хуҗаев Ташхуҗа Гомәр улы | 1967 | 192. Шәрифуллин Шамил Камил улы | 2005 | 204. ТАССРның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле | 1960 |
| 183. Хөсәенов Гали Кәрим улы | 1979 | 193. Шиһабетдинов Рәшит Садри улы | 2016 | 205. ТРның Дәүләт кыллы квартеты | 2002 |
| 184. Хөснетдинов Фатих Хөснетдин улы (Фатих Хөсни) | 1972 | 194. Шутиков Анатолий Иванович | 2001 | | |
| 185. Шабаев Марс Садри улы | 1976 | 195. Щетинин Игорь Дмитриевич | 2016 | | |
| 186. Шакирҗанова Лена Галимҗан кызы (Лена Шагыйрьҗан) | 2011 | 196. Юзеев Илдар Гафур улы | 1980 | | |
| | | 197. Юзиев Нил Гафур улы | 1974 | | |
| | | 198. Юнысов Миргазиян Закир улы (Миргазиян Юныс) | 2004 | | |

*5 нче кушымта*

### ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ФӘН ҺӘМ ТЕХНИКА ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ БҮЛӘГЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

| Фамилиясе, исеме, әтисе исеме | Бүләкләнү елы |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Абашев Альмир Рәшит улы | 2014 |
| 2. Абашев Рәшит Җәләлетдин улы | 2008 |
| 3. Абдрахманов Габдерәшит Солтан улы | 2006 |
| 4. Абдрахманова Рәйсә Шәрәфетдин кызы | 2000 |
| 5. Абдуллин Адел Илдус улы | 2016 |
| 6. Абдуллин Илдар Гариф улы | 2006 |
| 7. Абдуллин Илдар Шәүкәт улы | 2003 |
| 8. Абзалова Венера Галихан кызы | 2005 |
| 9. Авраменко Александр Никифорович | 2000 |
| 10. Аганин Александр Алексеевич | 2012 |
| 11. Аганов Альберт Вартанович | 2009 |
| 12. Азизова Алия Камил кызы | 2008 |
| 13. Акмаева Алия Әдһәм кызы | 2002 |
| 14. Аксёнов Евгений Михайлович | 2005 |
| 15. Аксютин Олег Евгеньевич | 2012 |
| 16. Акчурин Тимур Марат улы | 2009 |
| 17. Алексеев Андрей Георгиевич | 2016 |
| 18. Альтшулер Семён Александрович | 2006 |
| 19. Анашкин Владимир Николаевич | 2005 |
| 20. Антипин Игорь Сергеевич | 2008 |
| 21. Антипов Михаил Андреевич | 2012 |
| 22. Антонов Геннадий Петрович | 2012 |
| 23. Антонов Олег Геннадьевич | 2014 |
| 24. Апаков Рәшит Усман улы | 2005 |
| 25. Ардашева Евгения Павловна | 2009 |
| 26. Арзин Дмитрий Николаевич | 2015 |
| 27. Арсланова Алсу Айрат кызы | 2016 |
| 28. Артюхов Александр Владимирович | 2014 |
| 29. Астахов Сергей Васильевич | 2013 |
| 30. Ахунҗанов Алмаз Әсхәт улы | 1997 |
| 31. Әбҗәлилова Ләйсән Рәхим кызы | 2009 |
| 32. Әбүбәкеров Ришат Фазлетдин улы | 2004 |
| 33. Әбүзәров Рафаэль Хаҗи улы | 2003 |
| 34. Әбүталипова Людмила Николаевна | 2003 |
| 35. Әгълиев Хәйдәр Миңнемөхәммәт улы | 2000 |
| 36. Әкбәров Фоат Галимҗан улы | 1996 |
| 37. Әминов Камил Линар улы | 2005 |
| 38. Әминов Линар Кәшиф улы | 2006 |
| 39. Әминова Роза Мөхәммәт кызы | 2009 |
| 40. Әмиров Наил Бәһави улы | 2012 |
| 41. Әмиров Наил Хәбибулла улы | 1999 |
| 42. Әмирханов Марат Инкыйлап улы | 2010 |
| 43. Әһлуллин Илдар Рәүф улы | 2011 |
| 44. Әсләмов Илдар Равил улы | 2011 |
| 45. Әфләтунов Радик Әбүзәр улы | 2000 |
| 46. Әхәтов Марат Фарыйх улы | 2012 |
| 47. Әхмәдиев Фаил Габделбәр улы | 1994 |
| 48. Әхмәдиева Гөлнара Чулпан кызы | 2014 |
| 49. Әхмәдишин Фәрит Фоат улы | 2014 |
| 50. Әхмәдуллин Азат Гыйльмулла улы | 2014 |
| 51. Әхмәдуллин Рәзим Хәбибулла улы | 2006 |
| 52. Әхмәдуллин Роберт Рафаэль улы | 2013 |
| 53. Әхмәтвәлиев Рамил Нәфис улы | 2005 |
| 54. Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы | 2013 |
| 55. Әхмәтҗанов Рөстәм Рәсим улы | 2005 |
| 56. Әхмәтҗанов Шамил Халикъ улы | 2002 |
| 57. Әхмәтов Марат Готыф улы | 2000 |
| 58. Әхмәтов Наил Җиһангир улы | 2001 |
| 59. Әхмәтов Тимерхан Габдулла улы | 2010 |
| 60. Әхмәтов Финсур Готыф улы | 2013 |
| 61. Әхмәтова Лилия Тимерхан кызы | 2010 |
| 62. Әхмәтова Резидә Тимерхан кызы | 2010 |
| 63. Әхмәтханов Фарит Заһир улы | 2004 |
| 64. Әхмәтшин Рәис Асылгәрәй улы | 2010 |
| 65. Әхмәтшин Шамил Камил улы | 2012 |
| 66. Әхтәмов Әскәр Зөфәр улы | 2011 |
| 67. Әхтәмов Илдар Фоат улы | 1995 |
| 68. Әюпова Нәля Ринат кызы | 2013 |
| 69. Бабушкин Виталий Михайлович | 2014 |
| 70. Бабушкин Леонид Натанович | 2002 |
| 71. Бабынин Александр Александрович | 2008 |
| 72. Бажайкин Станислав Георгиевич | 2012 |
| 73. Бажирова Наилә Гыйльметдин кызы | 1998 |
| 74. Базаревская Венера Гыйльмеәхмәт кызы | 2012 |
| 75. Бакиров Илшат Мөхәммәт улы | 2012 |
| 76. Балуева Анна Сергеевна | 2014 |
| 77. Бәһаветдинов Флүр Нуретдин улы | 2010 |
| 78. Барабанов Владимир Иванович | 1997 |
| 79. Бардина Гөлшат Абдулла кызы | 1996 |
| 80. Басос Георгий Юрьевич | 2008 |
| 81. Баткис Григорий Семенович | 2005 |
| 82. Батыева Эльвира Салих кызы | 2007 |
| 83. Бахтин Анатолий Иосифович | 2011 |
| 84. Бахтиозин Рөстәм Фәрит улы | 2014 |
| 85. Баширов Заур Әхмәтулла улы | 1996 |
| 86. Башкирцева Наталья Юрьевна | 2013 |
| 87. Бәдретдинова Елена Радит кызы | 2016 |
| 88. Бәйрәмова Луиза Кәрим кызы | 2003 |
| 89. Безбородов Лев Петрович | 2000 |
| 90. Белоклоков Николай Борисович | 2000 |
| 91. Белоногов Виктор Анатольевич | 2004 |
| 92. Белоус Борис Прокофьевич | 2002 |
| 93. Бердников Алексей Владимирович | 2013 |
| 94. Береговой Андрей Николаевич | 2010 |
| 95. Берлин Александр Александрович | 2001 |
| 96. Беспалов Алексей Петрович | 2014 |
| 97. Бикмаев Илфан Фәрит улы | 2009 |
| 98. Бикмөхәммәтов Закирҗан Миңнемулла улы | 2004 |
| 99. Бикмурзин Азат Шәүкәт улы | 2006 |
| 100. Биктимерова Рәйсә Габдулла кызы | 2011 |
| 101. Бикчәнтәев Илдар Гомәр улы | 2001 |
| 102. Блохин Василий Иванович | 2015 |
| 103. Бобков Михаил Владимирович | 2006 |
| 104. Богданова Халидә Галимҗан кызы | 2011 |
| 105. Богряков Вячеслав Александрович | 2005 |
| 106. Боревский Борис Владимирович | 2004 |
| 107. Борһанов Әгъдәс Хөсәен улы | 2015 |
| 108. Борһанов Тәбриз Гыйльметдин улы | 2001 |
| 109. Боровик Роман Владимирович | 1995 |
| 110. Боровков Александр Григорьевич | 2011 |
| 111. Бохараев Рәис Гата улы | 2009 |
| 112. Будникова Юлия Германовна | 2007 |
| 113. Бурилов Александр Романович | 2008 |
| 114. Буров Андрей Иосифович | 2003 |
| 115. Буров Борис Владимирович | 2005 |
| 116. Бусыгин Владимир Михайлович | 2001 |
| 117. Бутаков Геннадий Петрович | 2005 |
| 118. Бушуев Алексей Сергеевич | 2016 |
| 119. Быков Юрий Владимирович | 2002 |
| 120. Вакула Андрей Ярославич | 2014 |
| 121. Валовский Владимир Михайлович | 2008 |
| 122. Валовский Константин Владимирович | 2008 |
| 123. Василова Нурания Зөфәр кызы | 2015 |
| 124. Васильев Валерий Архипович | 2003 |
| 125. Васильев Геннадий Иванович | 2008 |
| 126. Васянов Геннадий Павлович | 1998 |
| 127. Васясин Георгий Иванович | 1996 |
| 128. Вафина Альвина Әхмәт кызы | 1994 |
| 129. Вахитов Рәфыйк Кәлимулла улы | 1997 |
| 130. Вәлиев Инсур Габделхак улы | 1995 |
| 131. Вәлиев Рәмзи Кәлимулла улы | 2011 |
| 132. Вәлиева Ильвера Фәрит кызы | 2009 |
| 133. Вәлиуллин Госман Хәбибулла улы | 1994 |
| 134. Вәлишев Булат Мөхәммәт улы | 2002 |
| 135. Визель Александр Андреевич | 2012 |
| 136. Визель Андрей Оскарович | 1994 |
| 137. Вильданов Азат Фәрит улы | 1998 |
| 138. Винтер Любомир | 2000 |
| 139. Владимирова Ирина Сильвестровна | 2007 |
| 140. Войтович Евгений Дмитриевич | 2005 |
| 141. Волков Евгений Михайлович | 1995 |
| 142. Волкова Ирина Николаевна | 1995 |
| 143. Волкова Светлана Андреевна | 2003 |
| 144. Володиков Александр Васильевич | 2006 |
| 145. Володюхин Михаил Юрьевич | 2016 |
| 146. Вольфсон Светослав Исаакович | 2008 |
| 147. Воронин Евгений Константинович | 2011 |
| 148. Ворончихин ВладимирЯрополкович | 2002 |
| 149. Выштакалюк Александра Борисовна | 2013 |
| 150. Габәшев Рөстәм Солтан улы | 1994 |
| 151. Габбасов Айдар Минсабир улы | 1997 |
| 152. Габделмәҗитов Рафил Гыйниятулла улы | 1994 |
| 153. Габдрахманов Әлтәф Әфләтун улы | 1995 |
| 154. Габдуллин Габделхан Габдулла улы | 2007 |
| 155. Габетдинов Малик Салих улы | 1997 |
| 156. Гаврилов Илья Александрович | 2016 |
| 157. Газизов Алмаз Шакир улы | 1999 |
| 158. Газизов Илдар Сабир улы | 2010 |
| 159. Газизов Нәгыйм Вәли улы | 2003 |
| 160. Газизуллин Әхмәдулла Һади улы | 2003 |
| 161. Гаитов Марс Җамали улы | 2009 |
| 162. Гайнанова Лена Рәшит кызы | 2016 |
| 163. Гайнетдинов Альфред Ризван улы | 2006 |
| 164. Гайнетдинов Илгизәр Гыйльметдин улы | 2009 |
| 165. Гайнетдинов Ренат Хәмит улы | 2010 |
| 166. Гайнуллина Мөнирә Кәбир кызы | 2003 |
| 167. Гайсин Азат Фивзат улы | 2012 |
| 168. Гайсин Алмаз Фивзат улы | 2012 |
| 169. Гайсин Илшат Әхәт улы | 2000 |
| 170. Гайсин Ленар Гайнулла улы | 2010 |
| 171. Гайсин Фивзат Миңнебай улы | 2012 |
| 172. Гайфуллин Рөстәм Фәез улы | 2016 |
| 173. Галактионова Лидия Алексеевна | 1999 |
| 174. Галәветдинов Мансур Фәләхетдин улы | 2012 |
| 175. Галәвиев Шамил Шәйхи улы | 2006 |
| 176. Галәметдинов Юрий Геннадьевич | 2001 |
| 177. Галиев Илсур Илдар улы | 2003 |
| 178. Галиев Максуд Салих улы | 2003 |
| 179. Галиев Ринат Гали улы | 1994 |
| 180. Галиев Ринат Гыймаделислам улы | 1994 |
| 181. Галиев Ринат Харис улы | 2016 |
| 182. Галиева Дамирә Садыйк кызы | 2002 |
| 183. Галимҗанов Илсур Габделхак улы | 1999 |
| 184. Галимов Разиф Хиразетдин улы | 1997 |
| 185. Галиуллин Нияз Ильяс улы | 2007 |
| 186. Галкин Владимир Иванович | 2015 |
| 187. Ганиев Булат Гали улы | 2014 |
| 188. Ганиев Гали Газиз улы | 2001 |
| 189. Ганиев Илшат Газыйм улы | 2001 |
| 190. Ганиев Фоат Әшраф улы | 1994 |
| 191. Ганиева Тамилла Фәтхи кызы | 2010 |
| 192. Гарзавина Алевтина Викторовна | 2005 |
| 193. Гариев Равил Мансур улы | 2004 |
| 194. Гарипов Роберт Зариф улы | 1995 |
| 195. Гарифҗанов Надир Нургаяз улы | 2007 |
| 196. Гарифов Камил Мансур улы | 2001 |
| 197. Гарифуллин Илгиз Габделсамат улы | 2007 |
| 198. Гарифуллин Рафаэль Мәһәсим улы | 2013 |
| 199. Гарифуллин Ришат Госман улы | 2013 |
| 200. Гарифуллин Фоат Әсәдулла улы | 1994 |
| 201. Гатауллин Илгиз Габдулла улы | 2011 |

*5 нче кушымта (дәвамы)*

| 1 | 2 |
|---|---|
| 202. Гатина Роза Фатыйх кызы | 2013 |
| 203. Гатиятуллин Нәкыйп Сәләх улы | 2004 |
| 204. Гафаров Хәйдәр Зәйнулла улы | 1995 |
| 205. Гаффаров Харис Зариф улы | 1995 |
| 206. Гәрәев Рамил Суфиәхмәт улы | 1994 |
| 207. Гәрәев Раис Гыйният улы | 1997 |
| 208. Гәрәев Роберт Дәүләтша улы | 1997 |
| 209. Гәрәева Илнара Илгиз кызы | 2011 |
| 210. Гәрәйшин Альберт Сәях улы | 2012 |
| 211. Герасимов Константин Игоревич | 2012 |
| 212. Глазков Николай Михайлович | 2004 |
| 213. Гнездилов Олег Иванович | 2015 |
| 214. Гобәев Шамил Шәмси улы (үлгәннән соң) | 2009 |
| 215. Гобәйдуллин Айдар Тимергали улы | 2008 |
| 216. Гобәйдуллин Дамир Әнвәр улы | 2012 |
| 217. Гобәйдуллин Фоат Равил улы | 2013 |
| 218. Голенищев-Кутузов Вадим Алексеевич | 2011 |
| 219. Голованов Александр Иванович | 2004 |
| 220. Голубева Руфина Константиновна | 2016 |
| 221. Гомәров Әсхәт Мөхәммәтҗан улы | 2007 |
| 222. Гомәров Илшат Нургали улы | 2006 |
| 223. Гомәров Нәфис Фәрит улы | 2012 |
| 224. Гомәров Рөстәм Исхак улы | 2009 |
| 225. Гонюх Валерий Михайлович (үлгәннән соң) | 2003 |
| 226. Горбачёв Борис Фёдорович | 2003 |
| 227. Горбунов Сергей Александрович | 2009 |
| 228. Городний Виктор Исакович | 2011 |
| 229. Госманов Зәкәрия Габдулла улы | 2003 |
| 230. Госманов Миркасыйм Габделәхәт улы (үлгәннән соң) | 2012 |
| 231. Госманов Раис Госман улы | 2011 |
| 232. Гребнев Павел Николаевич | 1997 |
| 233. Григорьев Вениамин Демьянович (үлгәннән соң) | 2008 |
| 234. Грицишин Сергей Николаевич | 2010 |
| 235. Грошев Михаил Алексеевич | 2005 |
| 236. Губарева Валентина Степановна | 2005 |
| 237. Губская Валентина Петровна | 2010 |
| 238. Гуслякова Раиса Петровна | 2012 |
| 239. Гүзәлбаев Яхъя Зиннәт улы | 2005 |
| 240. Гыйбадуллин Камил Габделбар улы | 2002 |
| 241. Гыйбадуллина Фәүзия Солтан кызы | 2004 |
| 242. Гыйззәтуллин Васил Нурулла улы | 2003 |
| 243. Гыйззәтуллин Фоат Лотфулла улы | 1999 |
| 244. Гыйләҗев Искәндәр Аяз улы | 2016 |
| 245. Гыйләҗетдинов Илдар Абдулла улы | 2003 |
| 246. Гыйләҗетдинова Зәйнәп Шәйхи кызы | 1996 |
| 247. Гыйләҗетдинова Ирина Владимировна | 2013 |
| 248. Гыйльманов Әнәс Әнвәр улы | 2005 |
| 249. Гыйльманов Хәмит Хәмис улы | 2012 |
| 250. Гыйльметдинов Альберт Харис улы | 2010 |
| 251. Гыйльметдинов Наил Рәхмәтулла улы | 2001 |
| 252. Гыйльмуллин Ринат Абрек улы | 2009 |
| 253. Гыйльфанов Илдар Габделхак улы | 2000 |
| 254. Гыйльфанов Нух Хисам улы | 2001 |
| 255. Гыймадиев Сәлимҗан Салих улы | 1999 |
| 256. Гыйниятов Хәлил Зиннур улы | 2009 |
| 257. Гыйниятуллин Рәшит Әсхәт улы | 1995 |
| 258. Данилов Валерий Иванович | 1994 |
| 259. Даутов Рәис Нәүширван улы | 2005 |
| 260. Дәүләтшин Гамирҗан Миргаҗан улы | 2007 |
| 261. Дәүләтшин Җәгъфәр Зөфәр улы | 2001 |
| 262. Дәүләтшин Илдус Сөләйман улы | 2001 |
| 263. Дәүләтшин Таһир Зөфәр улы | 2001 |
| 264. Дәүләтшина Айгөл Ядкәр кызы | 2014 |
| 265. Дәүликамова Фәридә Илдус кызы | 2008 |
| 266. Двояшкин Нариман Камил улы | 2008 |
| 267. Дебердеев Рөстәм Якуп улы | 2001 |
| 268. Дегтярёва Ирина Александровна | 2014 |
| 269. Дедков Алексей Петрович | 2005 |
| 270. Демидов Алексей Иванович | 2001 |
| 271. Демидова Наталья Николаевна | 2005 |
| 272. Дёмин Тимур Викторович | 2016 |
| 273. Динмөхәммәтов Рамил Шәфыйк улы | 2012 |
| 274. Дистанов Урал Галимҗан улы | 1998 |
| 275. Дияров Ирек Нурмөхәммәт улы | 2010 |
| 276. Дмитриев Анатолий Валентинович | 2008 |
| 277. Дубровский Александр Владимирович | 2003 |
| 278. Дуглав Александр Васильевич | 2007 |
| 279. Дьяконов Герман Сергеевич | 2001 |
| 280. Дьячков Игорь Васильевич | 1998 |
| 281. Егоров Александр Васильевич | 2006 |
| 282. Егоров Иван Михайлович | 2013 |
| 283. Егорова Светлана Николаевна | 2015 |
| 284. Егорова Светлана Робертовна | 2006 |
| 285. Ежкова Асия Мәҗетдин кызы | 2014 |
| 286. Екименко Валентина Александровна | 2012 |
| 287. Екимова Алсу Мөхәммәтҗан кызы | 2006 |
| 288. Екимцов Сергей Александрович | 2014 |
| 289. Емельянов Виктор Михайлович | 2007 |
| 290. Енейкина Татьяна Александровна | 2013 |
| 291. Ерёмин Михаил Васильевич | 2007 |
| 292. Ермолаев Олег Петрович | 2004 |
| 293. Еров Юрий Васильевич | 2000 |
| 294. Есипов Анатолий Викторович | 1997 |
| 295. Жемков Юрий Михайлович | 1999 |
| 296. Жеребцов Евгений Петрович | 1996 |
| 297. Жиляев Геннадий Георгиевич | 1997 |
| 298. Җаббаров Әхтәм Хөсәен улы | 2014 |
| 299. Җаббаров Илдар Әхтәм улы | 2014 |
| 300. Җаббаров Руслан Габделрәкыйп улы | 2005 |
| 301. Җамалиева Фәния Фәйзрахман кызы | 2005 |
| 302. Җангуразова Фәридә Хөсәен кызы | 1996 |
| 303. Җәләлов Абдуллаҗан Абдулкадыйр улы | 2010 |
| 304. Җәләтов Марат Марс улы | 2005 |
| 305. Җәләтов Марс Шәйхразый улы | 1997 |
| 306. Җиһаншин Абдулла Абдрахман улы | 2001 |
| 307. Җиһаншин Айрат Госман улы | 2007 |
| 308. Җиһаншина Лилия Евгеньевна | 2007 |
| 309. Загурский Владислав Каликсович | 1999 |
| 310. Зайцев Валерий Иванович | 2004 |
| 311. Закиров Айрат Фикус улы | 2004 |
| 312. Закиров Әхмәтлатыйф Закир улы | 1991 |
| 313. Закиров Илгизәр Галиәхмәт улы | 2003 |
| 314. Закиров Илсөяр Вагыйзь улы | 2000 |
| 315. Закиров Рөстәм Фәйзрахман улы | 2004 |
| 316. Заһидуллин Ленар Рәфыйк улы | 2013 |
| 317. Заһиров Мәгъсүм Мөдәррис улы | 1996 |
| 318. Зарипов Илдар Нәкыйп улы | 1997 |
| 319. Зарипов Максут Мөхәммәтҗан улы | 2006 |
| 320. Зарипов Марат Хәй улы | 2013 |
| 321. Зарипов Равил Хаммат улы | 2005 |
| 322. Зарипова Лидия Павловна | 2001 |
| 323. Захарова Анна Андреевна | 2013 |
| 324. Захарова Евгения Ивановна | 1999 |
| 325. Зәйнуллин Альберт Габидулла улы | 2006 |
| 326. Зәкиев Булат Флүс улы | 2014 |
| 327. Зәкиев Мирфатыйх Зәки улы | 1994 |
| 328. Зәкиев Фәрит Әдип улы | 1997 |
| 329. Зверев Владислав Васильевич | 2010 |
| 330. Зефиров Андрей Львович | 1995 |
| 331. Зимин Геннадий Васильевич | 1999 |
| 332. Зиннәтуллина Клара Зыя кызы | 1994 |
| 333. Зиннуров Ильяс Авзал улы | 2004 |
| 334. Зиновьев Владимир Николаевич | 2010 |
| 335. Зорина Светлана Олеговна | 2005 |
| 336. Зубарев Виктор Владимирович | 2014 |
| 337. Зубова Наталья Дмитриевна | 2003 |
| 338. Зыякаев Зиннур Нурфаяз улы | 2000 |
| 339. Зыятдинов Азат Шәймулла улы | 2006 |
| 340. Зыятдинов Камил Шәһәретдин улы | 1996 |
| 341. Зыятдинов Раил Шәһәретдин улы | 2001 |
| 342. Ибәтуллин Морат Мәсгут улы | 2014 |
| 343. Ибәтуллин Равил Рөстәм улы | 1999 |
| 344. Ибәтуллин Рөстәм Хәмит улы | 2006 |
| 345. Ибраһимов Альберт Эдуард улы | 2004 |
| 346. Ибраһимов Данил Исмәгыйль улы | 2011 |
| 347. Ибраһимов Мөнәвәр Гомәр улы | 1998 |
| 348. Ибраһимов Наил Габделбәр улы | 2000 |
| 349. Ибраһимов Нәфис Мөдәррис улы | 1997 |
| 350. Ибраһимова Фатыйма Исхак кызы (үлгәннән соң) | 2016 |
| 351. Иваничев Георгий Александрович | 2006 |
| 352. Иванов Александр Аркадьевич | 2013 |
| 353. Иванов Александр Изосимович | 1997 |
| 354. Иванов Анатолий Александрович | 2000 |
| 355. Иванов Анатолий Васильевич | 1996 |
| 356. Иванов Борис Евгеньевич (үлгәннән соң) | 2007 |
| 357. Иванова Галина Ивановна | 2001 |
| 358. Идиятова Венера Рәис кызы | 2005 |
| 359. Идрисов Алмас Әхтәм улы | 2004 |
| 360. Идрисов Газыйм Җиһанша улы | 1996 |
| 361. Измайлов Бәхтияр Искәндәр улы | 2016 |
| 362. Икътисанов Валерий Әсхәт улы | 2014 |
| 363. Илһамов Марат Әкъсән улы | 2012 |
| 364. Ильинская Ольга Николаевна | 2008 |
| 365. Ильясов Әхәт Вахит улы | 1994 |
| 366. Ильясов Камил Әхәт улы | 2014 |
| 367. Ильясов Наил Әхәт улы | 2014 |
| 368. Ильясов Радик Сабит улы | 2007 |
| 369. Ильясов Шамил Гыймалетдин улы | 2009 |
| 370. Ионов Эрнест Филиппович | 1994 |
| 371. Исаева Наталья Александровна | 2012 |
| 372. Исмәгыйлев Илдус Хәниф улы | 2013 |
| 373. Исмәгыйлев Мәгъсүм Фәсәх улы | 1994 |
| 374. Исмәгыйлев Фәнзат Җәүдәт улы | 2009 |
| 375. Исхаков Альберт Яковлевич | 2012 |
| 376. Исхаков Дамир Мәүләви улы | 2003 |
| 377. Исхаков Радик Равил улы | 2016 |
| 378. Ишкаев Раувель Кәлимулла улы | 2001 |
| 379. Йосыпов Изил Галимҗан улы | 1994 |
| 380. Йосыпов Рөстәм Изил улы | 2004 |
| 381. Йосыпов Һарун Вәли улы (үлгәннән соң) | 1994 |
| 382. Йосыпова Галия Расыйх кызы | 1997 |
| 383. Йосыпова Гөлшат Гомәр кызы | 2010 |
| 384. Йосыпова Луиза Мәгъдәнур кызы | 2015 |
| 385. Кавиев Хәмит Заһир улы | 2006 |
| 386. Кадыйров Альберт Хәмзә улы | 2001 |
| 387. Казаков Евгений Петрович | 1994 |
| 388. Калинин Алексей Александрович | 2014 |
| 389. Камалов Абрик Закир улы | 2009 |
| 390. Камалов Владимир Гали улы | 2009 |
| 391. Камалова Динә Ил кызы | 2010 |
| 392. Кандаурова Галина Фёдоровна | 1994 |
| 393. Кантюков Рафаэль Рәфкать улы | 2012 |
| 394. Кантюков Рәфкать Габделхәй улы | 2012 |
| 395. Капитонова Нина Петровна | 1994 |
| 396. Карасева Алла Николаевна | 2013 |
| 397. Карасик Андрей Анатольевич | 2014 |
| 398. Каргин Юрий Михайлович | 1994 |
| 399. Карпенко Луиза Гайнетдин кызы | 2003 |
| 400. Карпухин Евгений Васильевич | 2002 |
| 401. Карташёв Валерий Борисович | 2002 |
| 402. Катаев Владимир Евгеньевич | 2014 |
| 403. Каюкова Галина Петровна | 2015 |
| 404. Каюмов Малик Шәфыйк улы | 2008 |
| 405. Каюмов Рубин Расыйх улы | 2013 |
| 406. Кәбиров Галимҗан Фазылҗан улы | 2013 |
| 407. Кәлимуллин Амил Камил улы | 2008 |
| 408. Кәлимуллин Салихҗан Минсабир улы | 2000 |
| 409. Кәримов Альберт Хәмзә улы | 1996 |
| 410. Кәримов Хәниф Зәки улы | 2004 |
| 411. Кемалов Алим Фәйзрахман улы | 2010 |
| 412. Кемалов Руслан Алим улы | 2010 |

*5 нче кушымта (дәвамы)*

| 1 | 2 |
|---|---|
| 413. Кессель Александр Рахмиэлевич (үлгәннән соң) | 2011 |
| 414. Киселёв Сергей Владимирович | 2013 |
| 415. Клоков Владимир Васильевич | 1996 |
| 416. Клочков Владимир Васильевич | 2009 |
| 417. Клочков Юрий Петрович | 2014 |
| 418. Клюшкин Иван Владимирович | 2014 |
| 419. Кобылянский Владимир Дмитриевич | 2000 |
| 420. Коваленко Валерий Игнатьевич | 2006 |
| 421. Кованова Галина Константиновна | 2005 |
| 422. Колесов Николай Александрович | 2002 |
| 423. Колычев Николай Матвеевич | 2011 |
| 424. Комлева Татьяна Ивановна | 2008 |
| 425. Коновалов Александр Иванович | 2008 |
| 426. Конюхова Татьяна Петровна | 2003 |
| 427. Копылов Александр Юрьевич | 2008 |
| 428. Кораблёв Михаил Григорьевич | 2002 |
| 429. Корбанов Рифат Җамал улы | 1999 |
| 430. Кормачёв Михаил Васильевич | 2007 |
| 431. Кормишин Евгений Григорьевич | 2012 |
| 432. Корнилов Анатолий Васильевич | 2003 |
| 433. Коробков Фёдор Александрович | 2008 |
| 434. Коробов Сергей Яковлевич | 2002 |
| 435. Корочкин Михаил Васильевич | 1999 |
| 436. Космачева Татьяна Фёдоровна | 2015 |
| 437. Косточко Анатолий Владимирович | 2013 |
| 438. Кочелаев Борис Иванович | 2007 |
| 439. Кочергина Ольга Сергеевна | 2008 |
| 440. Краснов Анатолий Васильевич | 2006 |
| 441. Краснов Максим Анатольевич | 2013 |
| 442. Кузовенин Владимир Алексеевич | 2000 |
| 443. Култаев Валентин Николаевич | 2011 |
| 444. Курбатова Надежда Васильевна | 2012 |
| 445. Куриненко Борис Михайлович | 2008 |
| 446. Куркин Михаил Иванович | 2011 |
| 447. Курочкин Леонид Михайлович (үлгәннән соң) | 2001 |
| 448. Лабунский Андрей Борисович | 2013 |
| 449. Лаврентьев Александр Петрович | 2002 |
| 450. Лавров Николай Иванович | 2008 |
| 451. Лавущенко Владимир Павлович | 2011 |
| 452. Лапин Анатолий Андреевич | 2013 |
| 453. Лапинская Татьяна Александровна | 2005 |
| 454. Ларочкина Ирина Андреевна | 2009 |
| 455. Латыйпов Шамил Камил улы | 2009 |
| 456. Латыйфуллин Фәрит Миңнеәхмәт улы | 2007 |
| 457. Лебедев Николай Алексеевич | 1999 |
| 458. Леванов Валерий Николаевич | 2004 |
| 459. Левин Иосиф Фомич | 1999 |
| 460. Левин Яков Абрамович | 1994 |
| 461. Лившиц Борис Михайлович | 2005 |
| 462. Литвин Алтер Львович | 1997 |
| 463. Литвинов Игорь Анатольевич | 2014 |
| 464. Лопатин Олег Николаевич | 2011 |
| 465. Лотфуллин Минсәгыйть Хәйрулла улы | 2015 |
| 466. Лощева Зоя Андреевна | 2014 |
| 467. Лузин Валерий Павлович | 2003 |
| 468. Лукин Анатолий Васильевич | 1998 |
| 469. Лукьянова Резедә Габдрәшит кызы | 2009 |
| 470. Лунёв Александр Тимофеевич | 2005 |
| 471. Лыгина Талия Зиннур кызы | 2003 |
| 472. Лысов Виктор Фёдорович | 1999 |
| 473. Любецкий Сергей Владимирович | 2010 |
| 474. Люлин Виктор Васильевич | 1999 |
| 475. Мазһаров Әхмәт Мазһар улы | 1998 |
| 476. Макаров Алексей Сергеевич (үлгәннән соң) | 1998 |
| 477. Маклаков Александр Иванович | 2008 |
| 478. Макшаков Станислав Борисович | 2002 |
| 479. Маликов Марсель Малик улы | 2004 |
| 480. Малкин Борис Залманович | 2006 |
| 481. Малков Игорь Сергеевич | 2013 |
| 482. Мамедов Вахид Абдулла оглы | 2014 |
| 483. Маннанов Фәнис Нурмөхәммәт улы | 1999 |
| 484. Мартынов Сергей Александрович | 2008 |
| 485. Матухин Евгений Леонидович | 2009 |
| 486. Матюшко Борис Николаевич | 1998 |
| 487. Махотин Александр Анатольевич | 2007 |
| 488. Мәҗитов Нәҗип Каюм улы | 1999 |
| 489. Мәхмүдов Рафаэль Хәбир улы | 1997 |
| 490. Мәхмүтов Мирза Исмәгыйль улы | 1996 |
| 491. Медведев Анатолий Михайлович | 2004 |
| 492. Медведева Нина Павловна | 2004 |
| 493. Мигачёв Станислав Александрович | 2011 |
| 494. Микусев Иван Егорович | 1999 |
| 495. Минәчетдинов Марат Канәфи улы | 2005 |
| 496. Мингалиев Газиз Фуат улы | 2014 |
| 497. Минҗанова Сәлимә Таһиятулла кызы | 2013 |
| 498. Минһаҗев Вагыйзь Васил улы | 1995 |
| 499. Минһаҗев Минтаһир Нургата улы | 2012 |
| 500. Минһаҗев Фидарис Фәләх улы | 1999 |
| 501. Минскер Карл Самойлович | 2001 |
| 502. Миңлебаев Шамил Хәмит улы | 1997 |
| 503. Миңнегулов Хатыйп Йосыф улы | 1995 |
| 504. Миңнеханов Нургали Миңнехан улы (үлгәннән соң) | 2003 |
| 505. Миңнеханов Рәис Нургали улы | 2003 |
| 506. Миргалиев Илнур Мидхәт улы | 2016 |
| 507. Миролюбов Леонид Михайлович | 2015 |
| 508. Миронов Владимир Фёдорович | 2013 |
| 509. Михайлов Марс Константинович | 2005 |
| 510. Михайлов Сергей Михайлович | 2004 |
| 511. Михайлов Юрий Михайлович | 2013 |
| 512. Мнекин Равил Васильевич | 1996 |
| 513. Мозаффаров Искәндәр Шәйхи улы | 2001 |
| 514. Моратова Софья Искәндәр кызы | 2003 |
| 515. Морозов Пётр Евгеньевич | 2016 |
| 516. Морошек Александр Ефимович | 2004 |
| 517. Мосабиров Мөнәвир Һади улы | 2009 |
| 518. Московцев Михаил Алексеевич | 2002 |
| 519. Мостафин Камил Сабир улы (үлгәннән соң) | 1998 |
| 520. Мостафина Асия Рафаэль кызы | 2008 |
| 521. Мотина Людмила Ивановна | 2012 |
| 522. Мотыйгуллин Равил Хәйдәр улы | 2009 |
| 523. Мохнаткин Михаил Гурьевич | 2007 |
| 524. Мохнаткина Елена Гордеевна | 2007 |
| 525. Мөгаллимов Абрик Фазлыйәхмәт улы | 1996 |
| 526. Мөслимов Ренат Хәлиулла улы | 1994 |
| 527. Мөхәммәдиев Әзһәр Гатаулла улы | 2008 |
| 528. Мөхәммәдиев Рамил Сафа улы | 2004 |
| 529. Мөхәммәдова Рәмзия Гыйният кызы | 2003 |
| 530. Мөхәммәтгалиев Радик Раиф улы | 2013 |
| 531. Мөхәммәтҗанова Гүзәл Вәли кызы | 2011 |
| 532. Мөхәммәтшин Зөфәр Гомәр улы | 2016 |
| 533. Мөхәммәтшин Рәфыйк Мөхәммәтша улы | 2005 |
| 534. Мурзов Александр Иванович (үлгәннән соң) | 2003 |
| 535. Мусина Розалинда Нури кызы | 2003 |
| 536. Муслинкин Абдрәхим Абдрәхим улы | 1994 |
| 537. Назимов Нәфис Әнәс улы | 2016 |
| 538. Насыйбуллин Арслан Валерьевич | 2007 |
| 539. Нәбиуллин Наил Гатиятулла улы | 2008 |
| 540. Нәҗметдинов Альфред Әдип улы | 2000 |
| 541. Нәҗмиева Резидә Разак кызы | 2005 |
| 542. Нәфыйков Әхтәм Зәки улы | 2004 |
| 543. Нәфыйкова Әдилә Әхәт кызы | 2009 |
| 544. Немежанов Марат Камил улы | 2009 |
| 545. Нигъмәтов Җәмил Газиз улы | 2007 |
| 546. Нигъмәтуллина Йолдыз Галимҗан кызы | 1999 |
| 547. Низаметдинова Гөлнара Борһан кызы | 2008 |
| 548. Низаметдинова Елена Игоревна | 2002 |
| 549. Низаметдинова Наилә Хәсән кызы | 2009 |
| 550. Низамов Илдус Галирзин улы | 2001 |
| 551. Никитин Валерий Григорьевич | 2006 |
| 552. Никитин Иван Николаевич | 1995 |
| 553. Никольский Евгений Евгеньевич | 1995 |
| 554. Ногайбәков Ардинат Гали улы | 2004 |
| 555. Нотфуллин Рамил Рәшит улы | 2013 |
| 556. Нуждин Владимир Иванович | 2011 |
| 557. Нургалиев Данис Карлович | 2009 |
| 558. Нуретдинов Илдус Әгъләм улы | 2010 |
| 559. Нуретдинов Минсәгыйрь Гайса улы | 2003 |
| 560. Нуретдинов Ядкәр Кәрам улы | 2004 |
| 561. Нуриев Ильяс Әхмәтгали улы | 2014 |
| 562. Нурмиев Илдар Наил улы | 2015 |
| 563. Нурмөхәммәтов Рафаил Сәет улы | 1997 |
| 564. Обухович Ольга Андриновна | 2011 |
| 565. Овчинин Андрей Викторович | 2005 |
| 566. Овчинников Алексей Леонидович | 1996 |
| 567. Овчинников Игорь Васильевич | 2001 |
| 568. Одинцов Виктор Владимирович | 2004 |
| 569. Орлов Григорий Алексеевич | 2009 |
| 570. Осыка Иван Иванович | 2005 |
| 571. Охотина Наталья Антониновна | 2007 |
| 572. Павлов Борис Петрович | 2007 |
| 573. Павлов Леонид Николаевич | 2002 |
| 574. Паймушин Виталий Николаевич | 2004 |
| 575. Панарин Александр Тимофеевич | 1997 |
| 576. Папуниди Константин Христофорович | 2013 |
| 577. Первушин Вадим Евгеньевич | 2005 |
| 578. Петин Владимир Сергеевич | 2003 |
| 579. Петров Александр Михайлович | 2005 |
| 580. Петров Семён Венидиктович | 2011 |
| 581. Петрушенко Денис Юрьевич | 2015 |
| 582. Пикуза Ольга Ивановна | 1999 |
| 583. Пименов Геннадий Георгиевич | 2008 |
| 584. Пискарёв Владимир Иванович | 2011 |
| 585. Пискунов Александр Алексеевич | 2004 |
| 586. Пичушкин Юрий Иванович | 2003 |
| 587. Плёнкин Александр Павлович | 1995 |
| 588. Плугина Татьяна Александровна | 2004 |
| 589. Поздеев Оскар Кимович | 2015 |
| 590. Полетаев Герман Иванович | 1995 |
| 591. Поникаров Сергей Иванович | 2013 |
| 592. Поникарова Анна Сергеевна | 2013 |
| 593. Пономарёв Сергей Николаевич | 2000 |
| 594. Пономарёва Мира Леонидовна | 2000 |
| 595. Потанин Владимир Петрович | 2012 |
| 596. Потёмкина Аделаида Матиновна | 2000 |
| 597. Правдюк Анатолий Николаевич | 2001 |
| 598. Пресняков Владимир Васильевич | 2008 |
| 599. Пухачёв Анатолий Павлович | 1999 |
| 600. Равилов Әбделхәмит Зариф улы | 1995 |
| 601. Равилов Рөстәм Хәмит улы | 1995 |
| 602. Разживин Дмитрий Александрович | 2007 |
| 603. Рамазанов Рәшит Газнәви улы | 2007 |
| 604. Рахманов Айрат Рәфкать улы | 2014 |
| 605. Рахманов Рәфкать Мәҗит улы | 2009 |
| 606. Рәмиев Зөфәр Зәйни улы | 2016 |
| 607. Рәфыйков Ринат Билал улы | 2014 |
| 608. Рәфыйкова Гөлнара Эрнст кызы | 2011 |
| 609. Рәхимов Равил Зөфәр улы | 1995 |
| 610. Резник Владимир Савич | 2014 |
| 611. Реут Валерий Иванович | 2000 |
| 612. Ризванов Нәүфәл Гаяз улы | 2009 |
| 613. Рогов Николай Васильевич | 2004 |
| 614. Рокицкий Михаил Рафаилович | 1997 |
| 615. Романов Геннадий Васильевич | 1997 |
| 616. Романова Ирина Петровна | 2010 |
| 617. Руль Леонард Константинович | 2005 |
| 618. Рыжкина Ирина Сергеевна | 2008 |
| 619. Сабирҗанов Гомәр Салих улы | 2005 |
| 620. Сабиров Рафаэль Шакирҗан улы | 2004 |
| 621. Сабиров Ринат Касыйм улы | 2008 |
| 622. Сабиров Ринат Сабир улы | 1995 |
| 623. Савельев Анатолий Александрович | 2004 |

*5 нче кушымта (дәвамы)*

| 1 | 2 |
|---|---|
| 624. Савельчев Алексей Петрович | 2007 |
| 625. Садретдинов Әгъләм Кыям улы | 2003 |
| 626. Садретдинов Фоат Заһит улы | 1997 |
| 627. Садыйков Альфред Фәйзрахман улы | 2002 |
| 628. Садыйков Бәһрам Газиз улы | 1998 |
| 629. Садыйков Зөфәр Барый улы | 1996 |
| 630. Садыйков Илгиз Фатыйх улы | 1997 |
| 631. Садыйков Илдус Хәбибрахман улы | 1997 |
| 632. Садыйков Марат Наил улы | 2013 |
| 633. Садыйков Равил Касыйм улы | 1995 |
| 634. Сайхунов Марат Вәлиулла улы | 2016 |
| 635. Салаев Юрий Николаевич | 2002 |
| 636. Салихов Әхәт Салих улы | 2006 |
| 637. Салихов Илгиз Мисбах улы | 1999 |
| 638. Салихов Илдар Газимҗан улы | 2000 |
| 639. Салихов Кев Миңнулла улы | 1998 |
| 640. Салихов Радик Рим улы | 2008 |
| 641. Салихов Рәшит Мәгъсут улы | 2005 |
| 642. Самарцев Виталий Владимирович | 2009 |
| 643. Самойлов Владимир Васильевич | 2007 |
| 644. Саттаров Гомәр Фәез улы | 2002 |
| 645. Саттаров Равил Зәйтүн улы | 2007 |
| 646. Саттаров Феликс Габделнур улы | 1998 |
| 647. Сафин Индус Нәвис улы | 2012 |
| 648. Сафин Марат Габдрахман улы | 1996 |
| 649. Сафина Нина Павловна | 2008 |
| 650. Сафина Фирсинә Шәймулла улы | 1999 |
| 651. Сафиуллин Әнәс Гадел улы | 2005 |
| 652. Сафиуллин Наил Әхмәт улы | 2013 |
| 653. Сафиуллин Рөстәм Сафиулла улы | 2004 |
| 654. Сафиуллин Фаикъ Нәби улы | 1997 |
| 655. Сафиуллина Гөлгенә Флүн кызы | 2005 |
| 656. Сәгыйтова Римма Надыйр кызы | 2000 |
| 657. Сәйфуллин Ренат Сәлах улы | 1994 |
| 658. Сәлахов Мәгъзүм Хәлимулла улы | 2010 |
| 659. Сәлимов Расих Бәхтигәрәй улы | 2009 |
| 660. Сәлимов Фәрит Ибраһим улы | 2009 |
| 661. Сәмитов Илдус Мөнир улы | 2009 |
| 662. Сәмитов Йосыф Юныс улы (үлгәннән соң) | 2009 |
| 663. Сәхапов Гаяз Җәмигъ улы | 1994 |
| 664. Сәхапов Миңнәхмәт Җәмил улы | 2004 |
| 667. Сәхәбетдинов Рифхәт Зиннур улы | 1997 |
| 665. Сәхәбетдинов Юрий Ефимович | 1996 |
| 666. Сәхибуллин Наил Габдулла улы | 2009 |
| 668. Сәхипов Ләззәт Сәет улы | 2006 |
| 669. Севрюгин Вячеслав Анатольевич | 2008 |
| 670. Селезнёв Владимир Андреевич | 1998 |
| 671. Семахина Любовь Анатольевна | 1994 |
| 672. Семёнов Владимир Фёдорович | 1995 |
| 673. Семёнов Вячеслав Энгельсович | 2014 |
| 674. Семёнов Эдуард Ильясович | 2013 |
| 675. Сенаторов Павел Петрович | 1995 |
| 676. Серебряков Борис Ростиславович | 1994 |
| 677. Сибгатуллин Фатих Сәубан улы | 2000 |
| 678. Сибгатуллин Җәлил Җәмил улы | 1999 |
| 679. Сибгатуллин Марат Нәби улы | 2003 |
| 680. Сибгатуллин Рафаэль Сәгыйдулла улы | 1996 |
| 681. Сигал Евгений Иосифович | 2004 |
| 682. Сидоркин Владимир Валентинович | 2004 |
| 683. Сидоров Владимир Павлович | 2005 |
| 684. Сидорук Евгений Александрович | 2006 |
| 685. Сизов Борис Алексеевич | 2004 |
| 686. Синяшин Олег Герольдович | 2007 |
| 687. Ситдыйков Айрат Габит улы | 2008 |
| 688. Ситдыйков Рөстәм Фәрит улы | 2003 |
| 689. Скворцов Александр Павлович | 2001 |
| 690. Скирда Владимир Дмитриевич | 2008 |
| 691. Смоленцев Александр Владимирович | 2013 |
| 692. Смыков Виктор Васильевич | 2004 |
| 693. Созинов Алексей Станиславович | 2012 |
| 694. Соколов Борис Сергеевич | 2000 |
| 695. Соколов Евгений Михайлович | 2002 |
| 696. Солдатов Виктор Павлович | 2002 |
| 697. Соловьёва Светлана Евгеньевна | 2008 |
| 698. Солтанбәков Булат Фәйзрахман улы | 2011 |
| 699. Солтанов Әлфәт Сәлим улы | 2007 |
| 700. Сон Эдуард Евгеньевич | 2012 |
| 701. Сопин Владимир Фёдорович | 1997 |
| 702. Сөләйманов Асаф Ибраһим улы | 1994 |
| 703. Сөләйманов Җәүдәт Шәүкәт улы | 2009 |
| 704. Староверов Александр Александрович | 2013 |
| 705. Староверова Елена Ивановна | 2013 |
| 706. Старостин Пётр Николаевич | 1994 |
| 707. Сташевски Зенон | 2005 |
| 708. Степанов Алексей Иванович | 2002 |
| 709. Стойков Иван Иванович | 2008 |
| 710. Стрельников Юрий Петрович | 1998 |
| 711. Студенский Михаил Николаевич | 2006 |
| 712. Студенцова Ирина Андреевна | 1994 |
| 713. Судыкин Александр Николаевич | 2015 |
| 714. Судыкин Сергей Николаевич | 2015 |
| 715. Суржко Николай Владимирович | 2013 |
| 716. Суслова Светлана Владимировна | 2003 |
| 717. Сухова Вера Александровна | 2009 |
| 718. Таҗиев Миргазиян Зәки улы | 2000 |
| 719. Таҗиев Рәфкать Минһаҗ улы | 2011 |
| 720. Тайсина Эмилия Әнвәр кызы | 2014 |
| 721. Талапин Павел Сергеевич | 2006 |
| 722. Тамакова Вера Павловна | 2016 |
| 723. Таһиров Индус Ризак улы | 2001 |
| 724. Таһиров Ленар Рәфгать улы | 2007 |
| 725. Таһиров Марсель Шәрифҗан улы | 2015 |
| 726. Таһиров Морат Салих улы | 2006 |
| 727. Таһиров Энгель Ризак улы | 2010 |
| 728. Тарасов Леонид Андреевич | 1997 |
| 729. Тарасова Татьяна Ивановна | 2012 |
| 730. Таюрский Дмитрий Альбертович | 2006 |
| 731. Тәхәветдинов Шәфәгать Фәхрази улы | 1996 |
| 732. Тейтельбаум Григорий Бенционович | 2007 |
| 733. Теплов Михаил Александрович (үлгәннән соң) | 2006 |
| 734. Тимофеев Валерий Фёдорович | 2005 |
| 735. Титов Вадим Игоревич | 2003 |
| 736. Тихвинский Индрик Николаевич | 1995 |
| 737. Тихомиров Борис Иванович | 2000 |
| 738. Тихонова Валентина Петровна | 2003 |
| 739. Торсуев Николай Павлович | 2004 |
| 740. Трегубова Резидә Зәбир кызы | 2003 |
| 741. Тремасов Михаил Яковлевич | 2013 |
| 742. Трепавлов Вадим Винцерович | 2016 |
| 743. Тронов Валентин Петрович | 1997 |
| 744. Трутнев Вячеслав Викторович | 2014 |
| 745. Туишев Ростислав Иванович | 2012 |
| 746. Туктамышов Наил Кадыйр улы | 2009 |
| 747. Тумашева Диләрә Гариф кызы | 1994 |
| 748. Тюрикова Раиса Павловна | 1996 |
| 749. Тюрин Анатолий Николаевич | 1998 |
| 750. Угрюмова Валентина Степановна | 1997 |
| 751. Уразгильдин Ильяс Әнис улы | 2006 |
| 752. Уразманова Рәүфә Кәрим кызы | 2003 |
| 753. Урецкий Ян Семёнович | 1996 |
| 754. Усманов Айтуган Гариф улы | 1994 |
| 755. Фадеев Владимир Гелиевич | 2000 |
| 756. Фадеева Александра Николаевна | 2006 |
| 757. Фадеева Ирина Дмитриевна | 2015 |
| 758. Фазлыев Рабис Тимерхан улы | 1994 |
| 759. Фазлыева Гүзәл Мидхәт кызы | 2010 |
| 760. Фатыйхова Сәгыйдә Фоат кызы | 1994 |
| 761. Фәйзрахманов Илдар Габделкәбир улы | 1998 |
| 762. Фәйзуллин Илфат Нәгыйм улы | 2012 |
| 763. Фәйзуллин Расыйх Нәфис улы | 2014 |
| 764. Фәйзуллин Рөстәм Мәхмүд улы | 1998 |
| 765. Фәрдиев Илшат Шәех улы | 2003 |
| 766. Фәррахов Айрат Зәки улы | 2012 |
| 767. Фәрхетдинов Риф Галләм улы | 1997 |
| 768. Фәрхуллин Ринат Гаяз улы | 2016 |
| 769. Фәттахов Рөстәм Барый улы | 2010 |
| 770. Фәттахов Яхъя Вәли улы | 2005 |
| 771. Фәтхиев Фарис Гаяз улы | 2015 |
| 772. Фәткуллин Наил Фидан улы | 2008 |
| 773. Фәхретдинов Альберт Ринат улы | 2005 |
| 774. Фәхретдинов Павел Сәгыйть улы | 1997 |
| 775. Фәхретдинов Равил Габдрахман улы | 1994 |
| 776. Фәхретдинов Рево Җиһанша улы | 2010 |
| 777. Фёдоров Игорь Владимирович | 2004 |
| 778. Федосеенко Наталья Викторовна | 2008 |
| 779. Федяев Владимир Леонидович | 2012 |
| 780. Филиппов Андрей Васильевич | 2008 |
| 781. Филиппов Виталий Петрович | 2006 |
| 782. Филиппова Надежда Константиновна | 2007 |
| 783. Фисинин Владимир Иванович | 2013 |
| 784. Фомин Вячеслав Анатольевич | 1998 |
| 785. Фролов Александр Иванович | 2000 |
| 786. Фурман Михаил Владимирович | 2000 |
| 787. Һадиев Таһир Галимҗан улы | 2000 |
| 788. Һадиуллин Әмир Гыйльмулла улы | 2000 |
| 789. Хаҗиев Рөстәм Рәхим улы | 2015 |
| 790. Хаҗипов Нәҗип Нәкыйп улы | 2013 |
| 791. Хаҗипов Нәриман Җәлил улы | 1996 |
| 792. Хаков Вахит Хөҗҗәт улы | 2006 |
| 793. Халиков Альфред Хәсән улы | 1994 |
| 794. Халиков Наил Альфред улы | 2003 |
| 795. Хан Сергей Александрович | 2012 |
| 796. Ханзафаров Назыйм Габдрахман улы | 1997 |
| 797. Ханнанов Марс Тәлгать улы | 2016 |
| 798. Ханнанов Рөстәм Госман улы | 2009 |
| 799. Харахашьян Эдуард Георгиевич (үлгәннән соң) | 2007 |
| 800. Харисов Ринат Гата улы | 2004 |
| 801. Харитонов Михаил Васильевич | 1996 |
| 802. Харлампиди Харлампий Эвклидович | 1994 |
| 803. Хафизҗанова Руфия Хафизҗан кызы | 1994 |
| 804. Хафизов Азат Рәлиф улы | 1999 |
| 805. Хацринов Алексей Ильич | 2010 |
| 806. Хәбибуллин Равил Гата улы | 2001 |
| 807. Хәбибуллин Рәфис Җәүдәт улы | 2013 |
| 808. Хәбибуллина Фәндилә Садри кызы | 2000 |
| 809. Хәбиров Рәис Әхәт улы | 2000 |
| 810. Хәбиров Фәрит Әхәт улы | 2008 |
| 811. Хәйбуллин Илдус Барый улы | 1998 |
| 812. Хәйбуллин Рөстәм Илдус улы | 2011 |
| 813. Хәйдәров Рәфыйк Әхмәт улы | 2003 |
| 814. Хәйретдинов Мөслим Гатият улы | 2008 |
| 815. Хәйретдинов Рамил Равил улы | 2008 |
| 816. Хәйруллин Ирек Әкрам улы | 1997 |
| 817. Хәйруллин Мөхәммәт Гыйльми улы | 2016 |
| 818. Хәйруллин Рөстәм Наил улы | 2016 |
| 819. Хәкимҗанов Илгизәр Нургизәр улы | 2007 |
| 820. Хәкимов Рафаил Сибгат улы | 2008 |
| 821. Хәлимов Рөстәм Хәмис улы | 2014 |
| 822. Хәмәдиев Ривнур Хаҗи улы | 1995 |
| 823. Хәмзин Рафат Әсван улы | 1996 |
| 824. Хәмидуллин Айдар Фаяз улы | 2015 |
| 825. Хәмидуллин Булат Лирон улы | 2016 |
| 826. Хәмитҗанов Нигъмәтҗан Хәмит улы | 2006 |
| 827. Хәмитов Равил Әнвәр улы | 2002 |
| 828. Хәмитов Хәниф Сабир улы | 1995 |
| 829. Хәсәнов Мансур Хәсән улы | 2005 |
| 830. Хәсәнов Радик Шәүкәт улы | 2006 |
| 831. Хәсәнов Рөстәм Шамил улы | 2003 |
| 832. Хәсәнова Динә Рөстәм кызы | 2016 |
| 833. Хәсәнова Миләүшә Ильяс кызы | 2016 |
| 834. Хәсәншин Гафур Шәйхулла улы | 2006 |
| 835. Хәяров Альберт Ибраһим улы | 2009 |
| 836. Хенниг Клаус Юрген | 2014 |
| 837. Хисаметдинов Алик Исмәгъзам улы | 2009 |
| 838. Хисамиев Ибраһим Габделхак улы | 2005 |
| 839. Хисамов Рәис Салих улы | 1994 |

*5 нче кушымта (дәвамы)*

| 1 | 2 | 1 | 2 | 1 | 2 |
|---|---|---|---|---|---|
| 840. Хлебникова Тамара Александровна | 1994 | 869. Шакирова Гайшә Исмәгыйль кызы | 2006 | 898. Шәфыйков Динмөхәммәт Сәйфетдин улы | 2005 |
| 841. Хөсәенов Васил Мөхәммәт улы | 1999 | 870. Шаманский Иосиф Львович | 1995 | 899. Шәфыйкова Рисәлә Әхәт кызы | 1995 |
| 842. Хөсәенов Җәүдәт Салих улы | 2003 | 871. Шаммасов Рафаэль Зәкәрия улы | 2002 | 900. Швецов Владимир Александрович | 2004 |
| 843. Хөсәенов Рәхимҗан Сабит улы | 1995 | 872. Шамов Александр Георгиевич | 2006 | 901. Шевченко Олег Андреевич | 1999 |
| 844. Хөсәенов Фидаил Миңнегали улы | 1995 | 873. Шаргин Вячеслав Павлович | 2002 | 902. Шелин Геннадий Густавович | 2003 |
| 845. Хөснетдинов Айрат Асаф улы | 2005 | 874. Шариков Геннадий Нестерович | 2000 | 903. Шеляпин Олег Павлович | 2011 |
| 846. Храпковский Григорий Менделевич | 2006 | 875. Шарнин Генрих Павлович | 1997 | 904. Шергина Илсөя Илгиз кызы | 1997 |
| 847. Хрущёва Ирина Константиновна | 2008 | 876. Шаталов Алексей Николаевич | 2013 | 905. Шиманский Владислав Владимирович | 2009 |
| 848. Хуҗин Фаяз Шәрип улы | 1994 | 877. Шатилов Владимир Михайлович | 2006 | 906. Шишкин Анатолий Всеволодович | 1998 |
| 849. Цепаева Ольга Викторовна | 2013 | 878. Шацких Павел Александрович | 2012 | 907. Шляхтин Николай Геннадьевич | 2010 |
| 850. Чабдаров Шамил Мидхәт улы | 1996 | 879. Шәвәлиев Рафаэль Фирнаял улы | 2015 | 908. Шулаева Марина Петровна | 2015 |
| 851. Чендарёв Владимир Владимирович | 1996 | 880. Шәехов Марс Фәрит улы | 2003 | 909. Щёлков Фёдор Лазаревич | 2002 |
| 852. Черевин Валерий Филиппович | 1997 | 881. Шәйдуллин Рафаил Вәли улы | 2005 | 910. Щелыванов Евгений Юрьевич | 2011 |
| 853. Черепанов Михаил Валерьевич | 2000 | 882. Шәймәрданов Равил Шамил улы | 2013 | 911. Юнысов Рәүф Әдһәм улы | 2000 |
| 854. Чувашев Искәндәр Рәмзи улы | 2014 | 883. Шәйхетдинов Рәшит Рәхип улы | 2007 | 912. Юнысов Фәйзрахман Сәлах улы | 1995 |
| 855. Чугунов Александр Николаевич | 2004 | 884. Шәйхетдинов Сабир Гафур улы | 1999 | 913. Юсупов Рүзәл Габдуллаҗан улы | 1998 |
| 856. Чуприна Николай Семёнович | 1995 | 885. Шәкүров Мөхәммәтфатыйх Шәкүр улы | 1999 | 914. Юсупова Татьяна Николаевна | 2015 |
| 857. Шагалов Валерий Александрович | 2005 | 886. Шәмсетдинов Валерий Гарәф улы | 1994 | 915. Якимов Алексей Васильевич | 1997 |
| 858. Шайтанов Олег Львович | 2004 | 887. Шәмсетдинов Илгизәр Габденур улы | 2008 | 916. Якимов Олег Алексеевич | 2003 |
| 859. Шакирҗанов Мәсгут Мәҗит улы | 2011 | 888. Шәмсиев Марат Нәҗми улы | 2016 | 917. Якупов Илгизәр Габделкаюм улы | 2000 |
| 860. Шакирҗанов Рәшит Әгъли улы | 2009 | 889. Шәрәфетдинов Дамир Рәүф улы | 2011 | 918. Якупов Радик Альберт улы | 2006 |
| 861. Шакирҗанов Рәшит Габдулла улы | 1998 | 890. Шәрәфиев Заһит Фоат улы | 2007 | 919. Якушкин Николай Михайлович | 2005 |
| 862. Шакиров Камил Тәфхит улы | 2003 | 891. Шәрәфиева Алсу Фатыйх кызы | 2007 | 920. Янилкин Виталий Васильевич | 2010 |
| 863. Шакиров Рафил Сабир улы | 2006 | 892. Шәрәфисламов Искәндәр Фоат улы | 2013 | 921. Яһүдин Шамил Габделхәй улы | 2010 |
| 864. Шакиров Рузалин Хәсән улы (үлгәннән соң) | 1999 | 893. Шәрипов Илгизәр Ибраһим улы | 2001 | 922. Яркәева Фәридә Фатыйх кызы | 2006 |
| 865. Шакиров Фәрит Хафас улы | 1999 | 894. Шәрипов Сәлимҗан Әхтәм улы | 2009 | 923. Ярмәкиев Искәндәр Энгель улы | 2007 |
| 866. Шакиров Фәрит Шәүкәт улы | 2010 | 895. Шәрипов Эдуард Нәфис улы | 2007 | 924. Яруллин Рафинат Самат улы | 2009 |
| 867. Шакиров Фоат Гафи улы | 1998 | 896. Шәрипова Маргарита Рәшит кызы | 2008 | 925. Яруллин Рәшит Низам улы | 2009 |
| 868. Шакиров Шамил Касыйм улы | 1997 | 897. Шәфигуллин Ринат Илдус улы | 2012 | | |

## ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНДӘ КУЛЛАНЫЛГАН ТӨП КЫСКАРТУЛАР

а. — авыл
абс. — абсолют
авг. — август
адм. — администрация, административ
адм.-терр. — административ-территориаль
акад. — академик, академия
акц. — акционерлык
апр. — апрель
арх. — архитектор
археол. — археология, археологик
архит-ра — архитектура
атказ. — атказанган
атм. — атмосфера
а.м. — атом массасы
а.х. — авыл хуҗалыгы
әзәрб. — әзәрбайҗан
башк. — башкорт
балетм. — балетмейстер
биол. — биология, биологик
вет. — ветеринария
б.к. — баш килеш
г-та — газета
б.э. — безнең эра
б.э.к. — безнең эрага кадәр
гарәп. — гарәпчә (гарәп теленнән)
гв. — гвардия, гвардияче
ген. — генераль
геогр. — география, географик
геол. — геология, геологик
геом. — геометрия, геометрик
гинекол. — гинекология, гинекологик
геоморфол. — геоморфология
гистол. — гистология
гыйн. — гыйнвар
грек. — грекча (грек теленнән)
губ. — губерна
дек. — декабрь
дис. — дисәтинә
д-р — доктор
ж-л — журнал
з-д — завод
зоол. — зоология
и.к. — иялек килеше
инстр-т — инструмент
илл. — иллюстрация
ин-т — институт
ингл. — инглизчә (инглиз теленнән)
исем. — исемендәге
ит. — итальянча (итальян теленнән)
к. — кара(гыз)
канд. — кандидат
к-та — кислота (исем янында)
К$^{o}$ — компания
кап. — капиталь (төзелеш)
каф. — кафедра
кв. — квадрат
к-з — колхоз
ком. — командир
ком-т — комитет
комис-т — комиссариат
комп. — композитор
комб-т — комбинат
конф. — конференция
коэф. — коэффициент
крист. — кристаллик
к/т — кинотеатр
күпл. — күплек (саны)
лаб., лаб-я — лаборатория
лат. — латинча (латин теленнән)
libр. — либретто
лингв. — лингвистика
макс. — максималь
матем. — математика, математик
мәс. — мәсәлән
мед. — медицина
метеорол. — метеорология
минерал. — минералогия
миним. — минималь
мифол. — мифология
млн. — миллион
млрд. — миллиард
монгол. — монголча (монгол теленнән)
морфол. — морфология, морфологик
муз. — музыкаль
нем. — немецчә (немец теленнән)
неол. — неологизм
норм. — нормаль
нояб. — ноябрь
окт. — октябрь
Окт. рев-циясе — Октябрь революциясе (1917)
пасс. — пассажир
пед. — педагогика, педагогия, педагогик
пос. — посёлок
пр-тие — предприятие
проф. — профессор, профессиональ
псевд. — псевдоним
психол. — психология, психологик
райком — район комитеты
райсовет — район советы
ревком — революцион комитет
рев. — революцион
рев-ция — революция
реж. — режиссёр
рентгенол. — рентгенология
респ-ка — республика
р-н — район
сан.-эпид. — санитария-эпидемиология
сент. — сентябрь
с.-д. — социал-демократлар
симф. — симфоник, симфония
скульп. — скульптор
сов. — совет(лар)
с-з — совхоз
соц. — социалистик
социол. — социология, социологик
ст. — станция
стат. — статистика, статистик
стомат. — стоматология
т. — том
темп-ра — температура
терр. — территориаль
терр-я — территория
технол. — технология, технологик
ун-т — университет
ур. — урам
уч-ще — училище
фарм. — фармацевтика, фармацевтик
фармакол. — фармакология
фарсы. — фарсыча (фарсы теленнән)
фән. — фәннәр
февр. — февраль
физиол. — физиология, физиологик
филол. — филология
филос. — философия
ф-ка — фабрика
ф-л — филиал
ф-ла — формула
ф-т — факультет
фр. — французча (француз теленнән)
һ.б. — һәм башкалар
һ.б.ш. — һәм башка шундый
ш. — шәһәр
штп — шәһәр тибындагы посёлок
ш.и. — шул исәптән
ш.у. — шулай ук
ш.у.к. — шулай ук кара
экз. — экземпляр

## ШӘҺӘР ИСЕМНӘРЕНДӘГЕ КЫСКАРТУЛАР
(библиографиядә)

Татар/рус телләрендә

А.-А. — Алма-Ата
Аш. — Ашхабад
Г. — Горький
Душ./Душ. — Дүшәнбе/Душанбе
Ер. — Ереван
К. — Казан/Казань
Киш. — Кишинёв
Л. — Ленинград
М. — Мәскәү/Москва
М.—Л. — Мәскәү—Ленинград/Москва—Ленинград
Н. Новгород — Нижний Новгород
Наб. Челны — Набережные Челны
Новосиб. — Новосибирск
Од. — Одесса
П. — Петроград (Петербург)
Ростов н/Д. — Ростов-на-Дону
СПб. — Санкт-Петербург
Тал. — Таллин
Таш. — Ташкент
Тб. — Тбилиси
Фр. — Фрунзе
Хар. — Харьков

Чит ил телләрендә

Amst. — Amsterdam
Antw. — Antwerpen
B. — Berlin
Balt. — Baltimore
Bdpst. — Budapest
Brat. — Bratislava
Brux. — Bruxelles
Buc. — Bucuresti
Camb. — Cambridge
Chi. — Chicago
Cph. — Copenhagen, Copenhague
Fr./M. — Frankfurt am Main
Gen. — Geneve
Hamb. — Hamburg
Hdlb. — Heidelberg
Hels. — Helsingfors, Helsinki
Ist. — Istanbul
L. — London
Los Ang. — Los Angeles
Lpz. — Leipzig
Mass. — Massachusetts
Melb. — Melbourne
Mex. — Mexico
Mil. — Milano
Münch. — München
N.Y. — New York
Oxf. — Oxford
P. — Paris
Phil. — Philadelphia
Rio de J. — Rio de Janeiro
S.F. — San Francisco
Stockh. — Stockholm
Stuttg. — Stuttgart
W. — Wien
Warsz. — Warszawa
Wash. — Washington
Z. — Zürich

Башка шәһәрләрнең исемнәре кыскартылмыйча бирелә.

## БИБЛИОГРАФИЯДӘГЕ КЫСКАРТУЛАР

әд. — әдәбият
әсәр. — әсәрләр
библиогр. — библиография
бюл. — бюллетень
вестн. — вестник
дис. — диссертация
докл. — доклад(лар)
журн. — журнал (лар)
зап. — записки
кис. — кисәк
кит. — китап
конгр. — конгресс
конф. — конференция
реф. — реферат
рец. — рецензия
т. — том
тәрҗ. — тәрҗемәче
төз. — төзүче
у. һәм е.к. — урыны һәм елы күрсәтелмәгән
хезм. — хезмәт(ләр)
чыг. — чыганак
энцикл. — энциклопедия

## АББРЕВИАТУРАЛАР

ААҖ — ачык акционерлык җәмгыяте
АҖ — акционерлык җәмгыяте
АКШ — Америка Кушма Штатлары
АТС — автоматлаштырылган телефон станциясе
БАССР — Башкортстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы
БДБ — Бәйсез Дәүләтләр Берлеге
БР — Башкортстан Республикасы
БҮБК — Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты
ВАСХНИЛ — Ленин исемендәге Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы фәннәре академиясе (Всесоюзная академия сельскохозяйственных наук имени Ленина)
ВДНХ — Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе (Выставка достижений народного хозяйства)
ВКП(б) — Бөтенсоюз коммунистлар (большевиклар) партиясе (Всесоюзная коммунистическая партия (большевиков))
ВЛКСМ — Бөтенсоюз ленинчыл коммунистик яшьләр союзы (Всесоюзный ленинский коммунистический союз молодёжи)
ВНИВИ — Бөтенсоюз ветеринария фәнни-тикшеренү институты (Всесоюзный научно-исследовательский ветеринарный институт)
ВНИИгеолнеруд — Бөтенсоюз руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе фәнни-тикшеренү институты (Всесоюзный научно-исследовательский институт геологии полезных ископаемых)
ВРК — Вакытлы революцион комитет (Временный революционный комитет)
ВЧК — Бөтенроссия гадәттән тыш комиссиясе (Всероссийская чрезвычайная комиссия)
ВЦСПС — Профсоюзларның бөтенсоюз үзәк советы (Всесоюзный центральный совет профессиональных союзов)
ГИДУВ — Табибләрнең белемен күтәрү дәүләт институты (Государственный институт для усовершенствования врачей)
ГЭС — гидроэлектростанция
ДОСААФ — Армия, авиация һәм флотка булышлык итү ирекле җәмгыяте (Добровольное общество содействия армии, авиации и флоту)
ДУП — дәүләт унитар предприятиесе
ЖБ — җитештерү берләшмәсе
ҖЧҖ — җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять
КамАЗ (КАМАЗ) — Кама автомобиль заводы
КБ — конструкторлык бюросы
КГБ — Дәүләт иминлеге комитеты (Комитет государственной безопасности)
КГҮ — Казан гыйльми үзәге
КОМУЧ — Учредительләр җыены әгъзалары комитеты (Комитет членов учредительного собрания)
КОМЗ — Казан оптик механика заводы
КП — Коммунистлар партиясе
КПО ВС — Казан хисаплау системалары җитештерү берләшмәсе (Казанское производственное объединение вычислительных систем)
КПСС — Советлар Союзы коммунистлар партиясе (Коммунистическая партия Советского Союза)
КЭМСТ — Хәзерге заман театрының конструктив тәҗрибә остаханәсе (Конструктивно-экспериментальная мастерская современного театра)
МК — Министрлар Кабинеты
МС — Министрлар Советы
МТС — машина-трактор станциясе
НГДУ — нефть һәм газ чыгару идарәсе (нефтегазодобывающее управление)
НКВД — Эчке эшләр халык комиссариаты (Народный комиссариат внутренних дел)
нэп — яңа икътисади сәясәт (новая экономическая политика)
ОГПУ — Дәүләтнең берләштерелгән сәяси идарәсе (Объединенное государственное политическое управление)
ОСОАВИАХИМ — Авиация һәм химия төзелешенә булышлык итү җәмгыяте (Общество содействия авиационному и химическому строительству)
ПТУ — профессиональ-техник училище
ПФА — Педагогия фәннәре академиясе
РАХФА — Россия авыл хуҗалыгы фәннәре академиясе
РВС — Революцион хәрби совет (Революционный военный совет)
РМА — Россия Мәгариф академиясе
РМФА — Россия Медицина фәннәре академиясе
РОСТО — Россия оборона-спорт техник оешмасы (Российская оборонно-спортивная техническая организация)
РСДРП — Россия социал-демократик эшчеләр партиясе (Российская социал-демократическая рабочая партия)
РСФСР — Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы
РФ — Россия Федерациясе
РФА — Россия Фәннәр академиясе
СА — Сәнгать академиясе
СК — спорт клубы
СССР — Совет Социалистик Республикалар Союзы
ТАССР — Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы
ТМР — төш магнит резонансы
ТР — Татарстан Республикасы
ТССР — Татарстан Совет Социалистик Республикасы
ТЭЦ — җылылык-электр үзәге (теплоэлектроцентраль)
ФА — Фәннәр академиясе
ФҖБ — фәнни-җитештерү берләшмәсе
ХКС — Халык комиссарлары советы
ХХС — Халык хуҗалыгы советы
ЦНИИгеолнеруд — Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк фәнни-тикшеренү институты (Центральный научно-исследовательский институт геологии нерудных ископаемых)
ЧК — Гадәттән тыш комиссия (Чрезвычайная комиссия)
ҮК — Үзәк Комитет
ҮБК — Үзәк Башкарма Комитеты
ЭПР — электрон парамагнит резонансы
ЮС — Югары Совет
ЯАҖ — ябык акционерлык җәмгыяте

## ЗУРЛЫК БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ КЫСКАРТУЛАРЫ

*А* — ампер
*а.б.* — астрономик берәмлек
*а.к.* — ат көче
*В* — вольт
*Вб* — вебер
*В·А* — вольт-ампер
*Вт* — ватт
*Гн* — генри
*Гц* — герц
*Гпа* — гектопаскаль
*Гс* — гаусс
*г* — грамм
*га* — гектар
*град* — почмакча градус
*Дж* — джоуль
*дБ* — децибел
*дал* — декалитр
*дптр* — диоптрия
*К* — кельвин
*кВт·сәг.* — киловатт-сәгать
*кал* — калория
*кар* — карат
*кг* — килограмм
*Кл* — кулон
*км* — километр
*л* — литр
*лк* — люкс
*лм* — люмен
*м.а.б.* — массаның атом берәмлеге
*м* — метр
*мг* — миллиграмм
*мин.* — минут
*мкм* — микрометр
*мм* — миллиметр
*Н* — ньютон
*окт* — октава
*Па* — паскаль
*рад* — радиан
*с* — секунд
°*С* — градус (Цельсий шкаласы буенча)
*сәг.* — сәгать
*см* — сантиметр
*т* — тонна
*Ф* — фарад
*ц* — центнер
*Э* — эрстед
*эВ* — электронвольт
‰ — промилле

## КАРТАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

(җәя эчендә бит саны күрсәтелә)

Т а р и х и  к а р т а л а р.
Сарапул өязе (168), Казан губернасында 1920 елгы «сәнәкчеләр» фетнәсе (230), Себер ханлыгы (254), Спас кантоны (366), Спас өязе (367), Казан губернасы крәстияннәренең 1878 елгы кузгалышлары (489), Татар халкының Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә таралып урнашуы (518–519), Татарстан АССР. 1921 ел (574–575).

Г е о г р а ф и к  к а р т а л а р.
Татарстан Республикасының физик картасы (566–567).

А д м и н и с т р а т и в  к а р т а л а р.
Саба районы (111), Сарман районы (171), Спас районы (367), Татарстан Республикасының административ картасы (568–569).

## КАРТАЛАРДА КАБУЛ ИТЕЛГӘН КЫСКАРТУЛАР

а. — авыл
исем. — исемендәге
пос. — посёлок
р-н — район
с-з — совхоз
ш. — шәһәр
штп — шәһәр тибындагы посёлок

## ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР

### ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАЙОННАРЫНЫҢ АДМИНИСТРАТИВ КАРТАЛАРЫНДА

**Торак пунктлар**

Татарстан Республикасы башкаласы — Казан шәһәре
Район үзәкләре

Төре буенча

ЛЕНИНОГОРСК — Шәһәрләр
КУКМАРА — Шәһәр тибындагы посёлоклар
*Тимәш* — Авыл тибындагы торак пунктлар

Яшәүчеләр саны буенча

10 000 һәм аннан артыграк
1000 нән 10 000 гә кадәр
500 дән 1000 гә кадәр
500 дән кимрәк

**Чик билгеләре**

Республика һәм өлкәләр арасында
Районнар арасында

**Юл билгеләре**

Тимер юллар
1Р 241 — Төп автомобиль юллары һәм аларның номерлары
Башка төр автомобиль юллары:
а) түшәүле юллар
б) түшәүсез юллар
Елгалар
Сусаклагычлар

### ТАССР КАНТОННАРЫ КАРТАЛАРЫНДА

**Чик билгеләре**

Татарстан АССР 1921 елда
Татарстан Республикасы 2014 елда
Татарстан АССР кантоннары 1921 елда

**Юл билгеләре**

Тимер юллар
Төп юллар (трактлар)
Башка юллар

### ӨЯЗЛӘР КАРТАЛАРЫНДА

**Чик билгеләре**

Россия империясенең 1890 нчы еллардагы губерналары
Өязләр

**Юл билгеләре**

Тимер юллар
Төп юллар (трактлар)
Башка юллар

## Татар энциклопедиясенең фәнни мөхәрририяте

**Археология.** Ф.Ш.Хуҗин (рәис), А.Ә.Борһанов, Рафаэль М.Вәлиев, Е.П.Казаков, А.Г.Ситдыйков.

**Архитектура.** Х.Г.Надыйрова (рәис), Г.Н.Айдарова, С.П.Саначин, Н.Х.Халитов.

**Астрономия.** Н.А.Сәхибуллин (рәис), Е.Е.Беляева, И.Ф.Бикмаев, Р.В.Заһретдинов, Н.Г.Ризванов.

**Биология.** А.А.Җәләлов (рәис), В.А.Бойко, В.И.Гаранин, Р.Я.Гыйльметдинов, Р.Х.Фәйзрахманова.

**География.** Ю.П.Переведенцев (рәис), А.Х.Газизуллин, Ю.А.Горшков, Э.П.Наумов, В.А.Рубцов.

**Геология.** Д.К.Нургалиев (рәис), У.Г.Дистанов, Р.Х.Мөслимов, В.М.Смелков, Р.Р.Хәсәнов.

**Дәүләт һәм хокук.** В.П.Малков (рәис), Н.В.Бахарев, Е.Б.Долгов, Б.Л.Железнов, Г.И.Курдюков, И.Г.Тарханов, Р.Ш.Хафизов.

**20 йөзгә кадәрге Татарстан һәм татар халкы тарихы.** И.Л.Измайлов (рәис), И.К.Заһидуллин, Ф.Г.Ислаев, А.Х.Мәхмүтова, Д.Г.Мостафина, Р.В.Шәйдуллин.

**20—21 йөз башы Татарстан һәм татар халкы тарихы.** И.Р.Таһиров (рәис), Р.К.Вәлиев, Ә.Г.Галләмова, Я.Я.Гришин, И.А.Гыйләҗев, Р.Р.Салихов.

**20 йөзгә кадәрге татар әдәбияты.** Х.Й.Миңнегулов (рәис), М.И.Әхмәтҗанов, Р.К.Ганиева, Н.Ш.Хисамов.

**20—21 йөзләр татар әдәбияты.** Д.Ф.Заһидуллина (рәис), А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Г.Галимуллин, Т.Н.Галиуллин, Р.М.Харисов.

**Икътисад.** Ф.Г.Газизуллин (рәис), В.П.Захаров, В.А.Мальгин, Ф.Н.Мөхәммәтгалиев.

**Массакүләм мәгълүмат чаралары.** В.З.Гарифуллин (рәис), Е.С.Дорощук, Р.А.Ратникова.

**Математика.** М.М.Арсланов (рәис), А.М.Елизаров, Э.В.Скворцов.

**Медицина. Сәламәтлек саклау.** М.К.Михайлов (рәис), Н.Х.Әмиров, А.С.Созинов, В.Х.Фазылов.

**Музейлар.** Г.Р.Нәҗипова (рәис), С.Ю.Измайлова, Е.И.Карташова, Р.М.Нургалиева, О.Е.Щелковская.

**Музыка.** Р.К.Абдуллин (рәис), В.Р.Дулат-Алиев, Р.Ф.Кәлимуллин, А.Л.Маклыгин, Ш.Х.Монасыйпов, З.Н.Сәйдәшева, В.М.Спиридонова.

**Педагогика, халык мәгарифе.** Җ.Г.Нигъмәтов (рәис), Ә.Н.Хуҗиәхмәтов, Ф.Г.Ялалов, И.Э.Ярмәкиев.

**Сәнәгать, төзелеш, транспорт, элемтә.** Ш.М.Вәлитов (рәис), С.А.Нәҗипова, Р.З.Рәхимов, И.Ш.Рахманкулов, К.Ф.Фәсхетдинов.

**Сынлы сәнгать.** Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова (рәис), Е.П.Ключевская, Д.Д.Хисамова.

**Театр сәнгате.** А.Г.Әхмәдуллин (рәис), М.Г.Арсланов, И.И.Илялова, Д.Ә.Гыймранова.

**Терлекчелек. Ветеринария.** Р.Г.Госманов (рәис), А.М.Алимов, Р.Ә.Әсретдинова, А.В.Иванов, К.Х.Папуниди, Ә.Х.Фазылҗанов, М.Ш.Шәкүров.

**Техника һәм технология.** Ш.М.Чабдаров (рәис), Р.И.Әдһәмов, О.Ш.Даутов, И.М.Закиров, С.О.Мирумянц.

**Торак пунктлар тарихы.** М.И.Әхмәтҗанов (рәис), Д.Г.Мостафина, А.И.Ногманов, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хәйретдинов.

**Үсемлекчелек.** Ф.З.Кадыйрова (рәис), Е.И.Захарова, М.Л.Пономарёва, И.П.Таланов.

**Фәлсәфә һәм дин.** Р.М.Мөхәммәтшин (рәис), В.П.Козлов, Н.М.Мөхәррәмов, Р.Ә.Нәбиев, Р.М.Нугаев, Ф.М.Солтанов.

**Физик культура һәм спорт.** Х.Х.Шәйхетдинов (рәис), А.Ш.Баһаветдинов, Н.Д.Бобырев, И.Г.Илдарханов, З.Н.Пантелеева.

**Физика.** К.М.Салихов (рәис), В.А.Голенищев-Кутузов, Ә.В.Ильясов, И.В.Овчинников, В.В.Самарцев.

**Фольклор.** Ф.И.Урманчеев (рәис), Л.Ш.Җамалетдинов, Х.Ш.Мәхмүтов.

**Хәрби эшлекләр, Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары.** И.Ш.Мостюков (рәис), Н.Х.Булатов, А.Ш.Кәбирова, С.Н.Погодин, В.Ф.Телишев, М.В.Черепанов.

**Химия һәм химия технологиясе.** В.П.Барабанов (рәис), Г.К.Будников, А.О.Визель, В.И.Галкин.

**Этнография.** Д.М.Исхаков (рәис), Р.Н.Мусина, Г.Р.Столярова, С.В.Суслова, Р.К.Уразманова.

**Энциклопедия басмаларын татар телендә әзерләү буенча фәнни мөхәрририят.** М.З.Зәкиев (рәис), М.И.Әхмәтҗанов, Р.М.Мөхәммәтшин, Д.Б.Рамазанова, Р.Ф.Рахмани, Р.Ә.Шакирҗанов, А.Г.Яруллина.

# Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты

Директор — тарих фән. д-ры, ТР ФАнең мөхбир әгъзасы, профессор И.А.ГЫЙЛӘҖЕВ
Директор урынбасары — пед. фән. д-ры, профессор Ф.Г.ЯЛАЛОВ
Гыйльми секретарь — тарих фән. канд., доцент М.З.ХӘБИБУЛЛИН

## Үзәкләр

**ЭНЦИКЛОПЕДИСТИКА ҮЗӘГЕ.** Мөдире — тарих фән. д-ры, профессор Р.В.Шәйдуллин.

**Татарстан һәм татар халкы тарихы энциклопедистикасы бүлеге.** Җитәкчесе — өлкән фәнни хезмәткәр, тарих фән. канд. И.Р.Вәлиуллин; баш фәнни хезмәткәр, тарих фәннәре д-ры, профессор Р.М.Вәлиев; әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, тарих фән. канд., доцент Г.С.Сабирҗанов; өлкән фәнни хезмәткәрләр: тарих фән. канд-тлары Р.Р.Батыршин, Ф.Г.Кәлимуллина, Ф.Г.Миңнеханов; фәнни хезмәткәр тарих фән. канд. Б.И.Сибгатов.

**Энциклопедия басмаларын татар телендә әзерләү бүлеге.** Җитәкчесе — әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, филол. фән. канд. А.Г.Яруллина; өлкән фәнни хезмәткәрләр: филол. фән. канд. Г.И.Каюмова, Ф.Р.Бәдретдинова, В.А.Габдрахманова, И.Х.Хәлиуллин; фәнни хезмәткәрләр: Л.К.Галиева, Ф.С.Гыйниятуллина, Р.Г.Зәкиева, Ф.Г.Камалетдинова, И.Г.Нигъмәтҗанов, Г.Х.Нургалиева.

**Фәнни мәгълүмат хезмәте бүлеге.** Әйдәп баручы фәнни хезмәткәрләр: техник фән. канд. Р.Р.Сәләхиев, Г.Р.Дәүләтьянова, С.А.Ярмөхәммәтова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: сәнгать фән. канд. Л.Н.Донина, Г.Х.Галимуллина, Ф.Ә.Ибраһимова, Л.Т.Мөхәммәтшина, Р.Н.Нурмөхәммәтов; фәнни хезмәткәрләр: А.Б.Насыйбуллина, Л.Т.Нигъмәтҗанова, Л.М.Сәхапова, Г.Ш.Хәйруллова, Л.Р.Хисамиева, Р.Ф.Шәрәпова; рәссам-конструктор Р.Н.Шакиров.

**ТӨБӘКНЕ ӨЙРӘНҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ-МӘДӘНИ ТИКШЕРЕНҮЛӘР ҮЗӘГЕ.** Мөдире — тарих фән. канд., доцент Л.М.Айнетдинова; әйдәп баручы фәнни хезмәткәрләр: а.х. фән. канд. Р.Ә.Әсретдинова, тарих фән. канд-тлары: Р.А.Айнетдинов, Е.Б.Долгов; өлкән фәнни хезмәткәрләр: а.х. фән. канд. Ф.Г.Борһанов, тарих фән. канд-тлары: Ч.Х.Саматова, А.Б.Солтанбәков, С.А.Фәйзуллин, филол. фән. канд. Р.Р.Мусабәкова, Э.В.Әбдрәхимова, С.Г.Белов, А.Н.Хәсәнова; фәнни хезмәткәрләр: Л.Р.Әскәрова, Ф.Ә.Әхмәтшина, Г.М.Габделхакова, О.В.Ерегин, Р.Э.Рәхмәтуллин.

**ТАТАР ДИАСПОРАСЫН ӨЙРӘНҮ ҮЗӘГЕ.** Мөдире — тарих фән. канд. Б.Л.Хәмидуллин; әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, тарих фән. канд. Р.Р.Ибраһимов; өлкән фәнни хезмәткәр, филол. фән. канд. З.З.Гыйләҗев; фәнни хезмәткәр Л.Р.Хәлилова.

* * *

**Хуҗалык эшләре хезмәте.** Е.С.Чиляков, Е.Н.Алькова, Р.В.Әминов, О.А.Бастраков, Р.Ә.Хөснетдинов, Р.Н.Хөснетдинова.

## ТЭ 5 нче томының авторлар исемлеге

Р.Ж.Абашев, В.Г.Абзалова, Г.Д.Аверьянов, А.А.Агафонов, С.С. Айдаров, Г.Н.Айдарова-Волкова, Р.К.Аймәт, Р.А.Айнетдинов, Л.М.Айнетдинова, Е.М.Аксёнов, И.Е.Алексеев, Е.П.Алексеева, Г.У.Аллабирдина, Т.А.Алмазова, И.М.Андреев, И.И.Андреева, М.В.Андриянов, Р.Н.Апкин, М.М.Арсланов, А.А.Арсланова, А.С.Асватуров, И.Н.Афанасьев, Н.И.Афанасьева, А.М.Ахунов, Р.И.Әдһәмов, Э.Г.Әлмәнова, Л.К.Әминов, А.В.Әминова, А.Н.Әмиров, Р.Ш.Әскәров, Л.Р.Әскәрова, Р.Ә.Әсретдинова, А.Г.Әхмәдуллин, М.И.Әхмәтҗанов, Р.Х.Әхмәтҗанов, Н.Ш.Әхмәтҗанова, Д.И.Әхмәтова, Ш.К.Әхмәтшин, Ф.Ә.Әхмәтшина, М.Ю.Әюпов, О.В.Бакин, М.Х.Бакиров, В.Г.Бакирова, Г.А.Балакин, Б.И.Барабанщиков, С.Г.Батталова, Р.Р.Батыршин, Н.М.Баянова, Р.Ф.Бәдретдинов, М.Ш.Бәдретдинова, Ф.Р.Бәдретдинова, Л.К.Бәйрәмова, С.Г.Белов, А.В.Беспятых, Т.В.Бизяева, Р.В.Билалов, Г.Н.Бирюлёв, Ю.А.Благов, Н.Д.Бобырев, В.Ф.Богоявленский, В.А.Бойко, Ф.Г.Борһанов, Р.А.Борһанова, А.А.Бредихин, Б.В.Буров, А.А.Бус, Л.Е.Бушканец, Т.К.Вәлиәхмәтова, Г.Б.Вәлиев, Е.К.Вәлиев, Л.С.Вәлиев, Н.М.Вәлиев, Рамил М.Вәлиев, Рафаэль М.Вәлиев, Р.Ш.Вәлиев, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, И.Н.Вәлиуллин, И.Р.Вәлиуллин, Э.С.Вәлишин, Л.Я.Воронова, Р.С.Габәшев, А.Габәши, Г.Г.Габделганиева, Х.Ә.Габделкаюмов, Р.Д.Габделмәҗитов, Г.М.Габделхакова, В.А.Габдрахманова, И.Р.Габдуллин, Н.Х.Газиев, Ә.Һ.Газизуллин, Ф.Г.Газизуллин, М.В.Гайнетдинов, Р.Р.Гайнов, М.Ж.Гаитов, Б.М.Галиев, И.М.Галиев, Л.К.Галиева, Р.М.Галиева, М.Ш.Галимова, Г.Х.Галимуллина, А.К.Галиуллин, Ә.Н.Галиуллин, К.Р.Галиуллин, Н.И.Галиуллин, Т.Н.Галиуллин, Ф.Ә.Ганиев, Р.К.Ганиева, В.И.Гаранин, Р.А.Гарәфетдинов, А.В.Гарзавина, З.Г.Гарипова, Ф.Г. Гарипова, А.Л.Гиммельфарб, А.М.Гобәйдуллин, С.Г.Гордиенко, В.Н.Горшков, М.Г.Госманов, Р.Г.Госманов, Д.М.Госманова, Я.Я.Гришин, Ф.Ф.Гулова, М.М.Гыйбатдинов, В.Н.Гыйззәтуллин, И.Г.Гыйззәтуллин, Н.Г.Гыйззәтуллин, Р.Н.Гыйззәтуллин, З.З.Гыйләҗев, И.А.Гыйләҗев, И.А.Гыйләҗетдинов, Д.Ә.Гыйммранова, Ф.С.Гыйниятуллина, Р.Н.Даутов, Р.В.Даутова, Ә.Х.Дәүләтшин, Г.М.Дәүләтшин, А.П.Дедков, Е.Б.Долгов, А.В.Дуглав, А.М.Дятлова, А.В.Егоров, А.М.Елизаров, Р.У.Елизарова, Г.Г.Емельянова, О.В.Ерёгин, Б.Л.Железнов, А.К.Жеребцов, А.В.Зайцев, Р.Ә.Закиров, Р.Р.Зарипов, И.К.Заһидуллин, Д.Ф.Заһидуллина, М.З.Зәкиев, Р.З.Зәкиев, Р.Г.Зәкиева, Н.В.Звёздочкина, Р.М.Зелеев, А.Л.Зефиров, Ф.С.Зыятдинов, Р.Р.Ибраһимов, Ә.И.Ибраһимова, Ф.И.Ибраһимова, А.А.Иванов, В.Б.Иванов, Е.П.Иванов, Д.П.Игънатьева, Г.Ж.Идрисов, И.Л.Измайлов, С.Ю.Измайлова, М.Е.Ильина, И.И.Илялова, С.И.Ионенко, А.Ф.Йосыпов, Р.Х.Йосыпов, Н.М.Йосыпова, Г.Г.Исмәгыйлев, Д.М.Исхаков, Р.Г.Исхакова, И.Г.Кадошникова, О.Х.Кадыйров, Ф.З.Кадыйрова, Е.П.Казаков, Ф.Г.Камалетдинова, Л.Р.Камалиева, И.М.Камалов, Р.Р.Камалова, Б.А.Канеев, Г.М.Кантор, И.О.Кармазина, Н.З.Капкаева, Е.В.Карпухин, Р.А.Кашапов, В.В.Кашина, Г.И.Каюмова, Ф.Г.Кәлимуллина, А.В.Климин, Е.П.Ключевская, А.А.Козин, Р.Ә.Колшәрипова, А.Е.Кондаков, Т.А.Кондратьева, Ю.Г.Коноплёв, М.В.Кормачёв, С.Ю.Краснобаева, С.В.Кузьминых, Е.В.Липаков, И.Ф.Лобашёва, Е.И.Ломако, Л.В.Луконина, Ю.А.Лукьянова, С.А.Лучкина, О.Д.Любарская, А.Л.Маклыгин, Н.Н.Максютова, Т.А.Малыгина, Р.С.Мансуров, Ю.В.Мансурова, Р.К.Мәҗитова, Р.Ф.Мәрданов, М.М.Мәүләтшин, Г.Я.Мәүлетова, А.Х.Мәхмүтова, Б.Р.Милицын, Л.И.Минһаҗева, Н.М.Минһаҗева, Х.Й.Миңнегулов, Г.Г.Миңнекәев, Ф.Г.Миңнеханов, Д.В Миңнуллин, Ж.С.Миңнуллин, М.Г.Миролюбов, А.Н.Миронов, М.К.Михайлов, С.М. Михайлова, И.Б.Михалевич, В.В.Мозжерин, В.И. Мозжерин, Ш.Х.Монасыйпов, В.М.Морадымова, В.В.Морозов, Л.М.Мортазина, Р.Ә.Мостафин, Д.Г.Мостафина, Ә.Г.Мөхәммәдиев, Р.Х.Мөхиярова, Р.Р.Мулләхмәтова, Л.В.Муравьёва, Р.Р.Мусабәкова, Г.С.Муханов, Г.П.Мягков, И.Н.Надыйров, Х.Г.Надыйрова, Т.М.Насыйров, В.А.Наумов, Э.П.Наумов, Р.Г.Нашарова, Ф.Г.Нәбиев, Н.И.Недашковская, Л.Ф.Недашковский, М.В.Недорезов, И.Г.Нигъмәтҗанов, Л.Т.Нигъмәтҗанова, И.Г.Низамов, И.М.Низамов, И.А.Новицкая, А.И.Новицкий, А.И.Ногманов, Г.Г.Ногманова, Г.Х.Нургалиева, Д.Р.Нуретдинова, С.Ш.Нуриев, Ф.Ф.Нуриева, А.В.Овчинников, Л.И.Овчинников, М.В.Овчинникова, Г.Е.Осипов, Г.Г.Осокина, Ю.И.Павлов, Н.К.Павлычева, Л.С.Панягина, К.Х.Папуниди, Г.А.Пахомов, Ю.П.Переведенцев, С.Г.Персова, В.В.Племенков, Л.Д.Полякова, С.Н.Пономарёв, М.Л.Пономарёва, Е.В.Порфирьева, В.П.Притыкин, С.И.Раимова, Д.Б.Рамазанова, Р.Ф.Рахмани, З.З.Рәмиев, М.Ф. Рәхимкулова, Р.Э.Рәхмәтуллин, Э.Х.Рәхмәтуллин, Н.Г.Ризванов, В.А.Рубцов, Г.С.Сабирҗанов, Р.М.Сабиров, Н.Г.Савельева, Б.Г.Садыйков, А.С.Сакаева, А.Л.Салагаев, Ф.Ш.Салитова, К.М.Салихов, Р.Р.Салихов, С.П.Саначин, Е.А.Сапаев, М.Г.Сафин, Р.С.Сафин, А.М.Сәгыйтова, М.А.Сәйдәшева, М.В.Сәлимгәрәев, Н.И.Сәфәргалиев, М.Ф.Сәфәров, Р.А.Сәхиева, Л.М.Свердлова, Л.А.Севастьянова, Т.В.Селезнёва, Ю.В.Сементовский, А.Я.Семичёв, Г.И.Середа, Б.И.Сибгатов, А.З.Сингатуллина, Р.Т.Сираева, Р.И.Ситдыйков, В.М.Смирнов, В.Я.Соловьёв, Б.Ф.Солтанбәков, Р.Р.Солтанова, Л.Р.Сөрмәтова, Л.Е.Спориус, А.Н.Старостин, П.Н.Старостин, Е.А.Стахов, О.Г.Столова, Г.Р.Столярова, Н.А.Субаев, А.Ю.Суслов, М.А.Сушенцова, Р.В.Таҗиев, Н.И.Таиров, Р.И.Такташ, Р.И.Тарнопольский, В.Р.Таһиров, И.Р.Таһиров, М.С.Таһиров, В.Ф.Телишев, Г.М.Тептин, А.Г.Терегулов, Н.И.Типтяров, Э.В.Тисенко, Л.С.Токсубаева, В.А.Трифонов, Д.М.Туган-Барановский, Г.П.Тулузакова, А.А.Турцев, А.М.Туфетулов, О.Л.Улемнова, Ф.Я.Уразаев, О.Н.Урбанова, Ф.И.Урманчеев, Р.Г.Усманов, А.Н.Фадеева, Ә.Х.Фазылҗанов, Г.Р.Фәйзрахманова, А.М.Фәйзуллин, Р.Ш.Фәйзуллин, С.А.Фәйзуллин, Я.В.Фәттахов, Д.С.Фәхретдинов, Р.Г.Фәхретдинов, Н.А.Фёдорова, В.Г.Федулов, А.Г.Хаҗиев, В.Х.Хаков, Н.А.Халиков, И.И.Халитов, Р.Ф.Халитов, Ю.М.Ханжин, И.К.Харисов, М.М.Хәбетдинова, М.З.Хәбибуллин, Р.Н.Хәбирова, Р.Г.Хәйретдинов, Р.Н.Хәйруллин, Л.Р.Хәлилова, И.Х.Хәлиуллин, Л.Ю.Хәлиуллина, Б.Л.Хәмидуллин, Л.Х.Хәмидуллин, Р.Я.Хәмитова, Р.Ш.Хәсәнов, Ф.М.Хисамова, В.Ю.Хитров, Р.И.Хөсәенов, Ф.Ш.Хуҗин, Р.А.Циунчук, С.М.Червонная, А.А.Чижевский, Р.Э.Числияков, Т.С.Чудинова, В.А.Шагалов, О.Л.Шайтанов, В.З.Шакиров, А.Р.Шамигулов, Ф.А.Шамонова, Р.Г.Шаһиева, Р.В.Шәйдуллин, Б.Ф.Шәкүров, М.Ш.Шәкүров, Р.И.Шәмсутов, А.А.Шәмсутова, Г.С.Шәрәфетдинов, Д.Р.Шәрәфетдинов, Ә.М.Шәрипов, С.М.Шәфигуллина, Е.Г.Шемелова, А.А.Шинкарёв, В.И.Шишкин, М.И.Шпекин, Н.В.Шулаев, В.А.Яковлев, Н.М.Якупова, Ф.Г.Ялалов, А.Г.Яруллина.

Тышлыкның макеты, «Биология», «Үсемлекчелек», «Ветеринария» бүлекләрендәге төсле иллюстрацияләр һәм таблицалар рәссам В.Е.Булатов тарафыннан эшләнде.
Махсус фотолар З.Г.Бәширов, Е.Г.Бычков, О.В.Ерёгин, И.М.Йосыпов, Р.Н.Шакиров тарафыннан әзерләнде.
Томда шулай ук Г.П.Бутаков, А.И.Галиев, М.Г.Гафуров, А.Г.Гаянов, Ф.С.Гобәев, В.А.Голенищев-Кутузов, Ш.Ф.Дәүләтшин, Д.Р.Йосыпов, В.Г.Марфин, М.М.Медведев, В.Ю.Соломахин, О.Г.Столова, А.Л.Яскович, И.В.Яценко архивларыннан һәм М.Җәлил исем. Татар опера һәм балет театры (Р.Һ.Такташ), Г.Камал исем. Татар академия театры (Л.Г.Шакирҗанова), В.И.Качалов исем. Казан Зур драма театры (Ю.С.Копылов) музейлары, Казан (Идел буе) федераль университеты Геология музее (В.В.Силантьев), В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясе фотоархивы (Н.Г.Ризванов) фондларыннан алынган фоторәсемнәр һәм слайдлар файдаланылды.
Иске Казан фотографияләре А.И.Дубин, Г.В.Фролов коллекцияләреннән алынды.

Томның материалларын туплауда ТР Дәүләт архивы (директоры С.Т.Рәхимов). Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И.Лобачевский исем. фәнни китапханәсе (директоры Е.Н.Струков), ТР Милли китапханәсе (директоры С.Р.Җиһаншина), ТР Милли музее (директоры Г.Р.Нәҗипова), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее (директоры Р.М.Нургалиева) хезмәткәрләре катнашты.

ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты бу томны әзерләүдә зур ярдәм күрсәткәннәре өчен ТР ФА аппаратына, ТР буенча Дәүләт статистикасы федераль хезмәт территориаль оешмасына (рәисе В.П.Кандилов), ТРның Архив эшләре буенча дәүләт комитетына (И.Х.Әюпова), ТРның Мәгълүматлаштыру һәм элемтә (Р.А.Шәйхетдинов), Икътисад (А.А.Здунов), Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек (М.Г.Әхмәтов), Мәгариф һәм фән (Э.Н.Фәттахов), Мәдәният (А.М.Сибагатуллин), Сәламәтлек саклау (Г.Ю.Вафин) министрлыкларына, Казан (Идел буе) федераль университеты (ректоры И.Р.Гафуров), Казан дәүләт консерваториясе (ректоры Р.К.Абдуллин), Казан дәүләт медицина академиясе (ректоры Р.Ш.Хәсәнов), Казан дәүләт медицина университеты (ректоры А.С.Созинов), Казан дәүләт техник университеты (ректоры А.Х.Гыйльметдинов), Казан дәүләт технология университеты (ректоры Г.С.Дьяконов), Казан дәүләт аграр университеты (ректоры Җ.И.Фәйзрахманов); ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (директоры К.М.Миңнуллин), Тарих институты (директоры Р.С.Хәкимов), ТР ФАнең Археология институты (директоры А.Г.Ситдыйков), Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк фәнни-тикшеренү институты (директоры Е.М.Аксёнов), Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты (директоры М.Ш.Таһиров) галимнәренә һәм белгечләренә зур рәхмәтен белдерә.

Татар энциклопедиясенең 5 нче томын әзерләүдә төрле вакытта катнашучылар: фәннәр докторлары: Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, Ф.Г.Гарипова, Ф.С.Зыятдинов, Е.П.Казаков, Н.Н.Максютова, Х.Г.Надыйрова, Ф.Ш.Сәлитова, Р.Г.Усманов, Ф.И.Урманчеев, Ә.Х.Фазылҗанов; фәннәр кандидатлары: В.Г.Бакирова, Ю.А.Благов, Н.Д.Бобырев, Г.Н.Булатова, М.Я.Гаитов, Р.Г.Исхакова, И.Г.Кадошникова, Г.Г.Осокина, Э.Х.Рәхмәтуллин, Э.Г.Сәйфетдинова, Р.Ә.Шакирҗанов; фәнни хезмәткәрләр: В.Г.Абзалова, И.Н.Афанасьев, Р.С.Вафина, Х.Ә.Габделкаюмов, Р.И.Гурьянова, Д.Ә.Гыймранова, Т.П.Жучкова, Л.Р.Камалиева, Ф.Г.Макарова, А.Х.Мәхмүтова, Н.Ф.Мироновская, Г.Я.Мәүлетова, Ф.Ф.Нуриева, Р.И.Раскулова.

Текстларны компьютерда җыю һәм макетка салуда «Jahat Lab., KAI» лабораториясенең (җитәкчесе Р.Р.Имамов) Jahat™ программалар пакеты кулланылды.

**Татар энциклопедиясе:** 6 томда / Баш мөхәррир М.Х.Сәлахов, җаваплы мөхәррир Г.С.Сабирҗанов. — Казан: ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2016. — **5 т.**: Р–Та. — 728 бит, ил., карталар.

ISBN 978-5-902375-12-8

Татар энциклопедиясе — татар халкы һәм Татарстанның борынгы чордан алып безнең көннәргә кадәрге тарихын һәм яшәешен яктырткан беренче фәнни универсаль басма. Китапта 2938 мәкалә (1267 биографик), 952 иллюстрация (564 төсле) урын алды.

**Tatar ensiklopediəse:** 6 tomda / Baş mөxərrir M.X.Səlaxov, cavaplı mөxərrir Ğ.S.Sabircanov. — Qazan: TR FAne▯ Tatar ensiklopediəse həm tөbəkne өyrənü institutı, 2016. — **5 t.**: R–Ta. — 728 b., il., kartalar.

Tatar ensiklopediəse — tatar xalqı həm Tatarstannı▯ borıngı zamannardan alıp bezne▯ kөnnərgə qadərge tarixın həm yəşəyeşen yaqtırtqan tatar telendəge berençe universal' basma. Tomda 2938 məqalə (1267 şəxeslərgə qarıy), 952 illustratsiə (564 tөsle).

**Татар энциклопедиясе**

5 нче том

Басарга кул куелды 29.12.2016. Махсус кәгазьдә. Форматы 84×108/16.
«Петербург» гарнитурасы. Офсет ысулы белән басылды.
Шартлы басма табагы 76,44. Нәшер-хисап табагы 136,64.
Заказ № 44.

ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты.
420015, Казан шәһәре, Пушкин урамы, 56.
e-mail: info-ite@mail.ru

Әзер оригинал-макеттан «Фолиант» ҖЧҖ басмаханәсендә бастырылды.
420111, Казан шәһәре, Профсоюз урамы, 17 В.
Тел. (843) 292-27-25
Web: print-kzn.ru